ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

## V том
## С–Т

Казан • 2019

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

*Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә төрле, шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына урнаштыру авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

**Проект җитәкчесе –** А.Ә. Тимерханов

**Төзүче авторлар:**

Э.И. Сафина, И.И. Сабитова, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Р.Т. Сәфәров, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, Ф.И. Таһирова, Ф.Ф. Гаффарова , А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина

**Фәнни редакторлар:**

Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров

**Бәяләүчеләр:**

*М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университеты Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы*
(мөдире – И.С. Насипов, филология фәннәре докторы, профессор);
*Яр Чаллы дәүләт педагогика университетының
татар теле һәм әдәбияты, аларны укыту методикасы кафедрасы*
(мөдире – Р.Р. Галиуллин, филология фәннәре кандидаты, доцент)

**Т 23** **Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** V том: С – Т. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 908 б.
ISBN 978-5-93091-298-2

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлеге күләме һәм эчтәлеге белән мондый төр сүзлекләрнең иң тулысы. Ул татар тел белеме, тюркология һәм гомуми лексикографиянең ирешкән уңышларын, уңай тәҗрибәсен исәпкә алып төзелде.

V томда барлыгы 13300 дән артык сүз һәм 1800 гә якын фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә кертелде. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланыштагы актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз чаралары белән ясалган неологизмнар, кабат активлашкан сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

Сүзлек киң катлау укучыга, шулай ук төрле фән белгечләренә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-298-2**
© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2019

## СҮЗ БАШЫ

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлегенең I томына А – В, II томына Г – Й, III томына К, IV томына Л – Р хәрефенә башланган сүзләр кертелде. V том С – Т хәрефләренә башланган сүзләрдән тора. Сүзлек турында белешмә материаллар тулы рәвештә I томда бирелде.

Проект җитәкчесе һәм координаторы – А.Ә. Тимерханов.

Сүзлекнең V томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: Р.Т. Сәфәров – С хәрефе (С – саф I); Т хәрефе (теми – тешәү II); Э.И. Сафина – С хәрефе (саф II – силикат); Т хәрефе (тулыксау – тыңлау; тәрәшләү – төп (26 мәгъ.); Г.Г. Саберова – С хәрефе (силикатлау – статус); Т хәрефе (тыңлаулы – тәмәкелек); А.Ф. Гайнетдинова – С хәрефе (статус-кво – схоласт); Ю.Ф. Борһанова – С хәрефе (схоластика – сәүдә); А.Ә. Тимерханов – С хәрефе (сәүдәгәр – сүтү); Ф.И. Таһирова – Т хәрефе (Т – таганлау; тач I – тез; түбәнәйтү – түшлек); О.Н. Галимова – Т хәрефе (тагарак – тахта, төртү (2 мәгъ.) – төшем I); Ф.Ф. Гаффарова – Т хәрефе (тезген – тембрлы; тәмәкече – тәрәшләнү); И.И. Сабитова – Т хәрефе (тең – тулы; төшем II – түбәнләнү); Р.Р. Абдуллина – Т хәрефе (төп ◊: төп асылда – төртү (1 мәгъ.)

Сүзлек материалы элекке алфавит тәртибендә бүленде, соңыннан хәзерге алфавитка туры китереп урнаштырылды.

Сүзлекнең V томын Ф.И. Таһирова һәм Р.Т. Сәфәров һәр икесе тулысынча редакцияләде.

Томны туплау, материалларны берләштереп, алфавитка салу эшен Р.Т. Сәфәров башкарды.

Авторларның исемнәрен албиттә күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Хезмәтнең һәр томы электрон форматта http://antat.ru/ru/iyli/publishing/book/ адресы буенча урнаштырылган.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

# СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

## I. Сүзлеккә сүзләр алу тәртибе

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге әдәби тел сүзләре һәм фразеологик берәмлекләре тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр (**БА́ЗИС, БАКТЕ́РИЯ, ТИГЕЗЛӘМӘ, ФО́РМУЛА** һ.б.);

ә) газета-журналларда урын алган күпчелек иҗтимагый-сәяси терминнар (**ДОТА́ЦИЯ, ВӘКАЛӘТ, РЕФЕРЕ́НДУМ, РЕЙД** һ.б.);

б) моңа кадәр басылып чыккан лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән аерым терминнар яки аларның тәрҗемәләренең шактый күләме (**АСТӨШЕРМӘ, БАШЛАМ, БИЗӘМ, ӨЛГЕ, ТАМГАХАНӘ, ТЕРКӘ́Ү** һ.б.);

в) бүгенге көн өчен яңа булган, вазгыятьнең үзгәрүе белән килеп кергән, язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә очраган Европа телләреннән алынган сүзләр (**БА́ЙКЕР, БАЙТ, БО́НУС, ДИВИДЕНД, ДИ́ЛЕР, ИПОТЕ́КА** һ.б.);

г) дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр (**БАКЫЙ, БАПТИЗМ, БӘДӘЛ, БӘРМӘНЧЕК, НАРДУГАН, ФАНИ** һ.б.);

д) яңадан кулланышка актив кереп бара торган, телдә кабат торгызылган искергән сүзләр (**БАГАВЫЛ, БАЕК, БАЙСА, БАЛГА** һ.б.);

е) хәзерге чорда активлашкан һәм урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнелә торган борынгы әдәбиятта очраган гарәп һәм фарсы телләреннән кергән шактый алынма сүзләр (**БАБ, БАГБАН, БАЗАРКӘН, ҖӘНҮБ, ИГАНӘ, ИГЪДАДИ, ИГЪТИБА́РӘН** һ.б.);

ж) тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр (**ӘДЕРНӘ, БАРЫМТА, БАТМАН, БАТРАК, БИЗМӘН, КАБИЛӘ, КАГАН, КАГАНЛЫК, НӨГӘР** һ.б.);

җ) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләр (**ӘНӘЧӘ, БАДЪЯН, БАШБАТА, КАБЫГУ, КАЗЫМА, ШАМА** һ.б.);

з) матур әдәбият әсәрләрендә очраган яки хәзерге әдәби телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре (**БӘЛШӘЮ, БӘРГӘЛӘШ, БЕЛӘМӘН** һ.б.);

и) киң кулланышка кергән яңа реалияләрне белдерү өчен, телнең үз җирлегендә ясалган яки мәгънәләре киңәйгән яңа сүзләр (**БАКЫЙЛЫК, БАРЛАМА, БАСМАК, ИГАНӘЧЕ, КОЛАКСА, КЕРТЕМ, ЭШМӘКӘР** һ.б.).

§ 3. Сүзлек берәмлеге итеп барлык грамматик сүз төркемнәренә дә караган сүзләр алынды. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре төп сүз мәкаләсендә күрсәтелде.

**ӘВӘРӘ** *и. фар.* **1.** Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса, ireккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

§ 4. Мөстәкыйль сүзлек берәмлеге буларак, тамыр сүзләр белән беррәттән, барлык сүз төркемнәренә дә караган төрле типтагы ясалма сүзләр дә кертелде. Шул исәптән: а) кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (**ӘЙЛӘНЕШ, ВӘКАРЬЛЕК, ҖӘМГАТЬЧЕЛЕК** һ.б.); ә) саф кушма сүзләр (**АМПЕРМЕТР, АРПАБАШ, АЯ́ГҮРӘ, БАШКИСӘР** һ.б.); б) кыскартылган кушма сүзләр (**БАТРАЧКОМ, БЕНЗОВОЗ, РАБФАК** һ.б.); в) парлы сүзләр (**АНДА́-МОНДА, БАШ-АЯК, КҮРШЕ́-КҮЛӘН, САВЫТ-САБА** һ.б.); г) компонентлары аерым язылса да, кушма һәм тезмә сүзләр (**БАКА́ ЕФӘГЕ, БАКА́ ЯФРАГЫ, БАЛА́Н БАРМАК, БАСЫМЧА́К ИТҮ, ВАСЫЯ́ТЬ КЫЛУ, КЫШТЫР-КЫШТЫР ИТҮ** һ.б.).

§ 5. Киң кулланылышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелде (**АВИА-, АВТО-, АГРО-, -АРА, БИ-, БИО-, НЕО-, -СЫМАННАР** һ.б.).

§ 6. Сүзлектә түбәндәге сүзләр бирелмәде: а) үтә профессиональ сүзләр, ягъни фәннең һәм техниканың тик аерым тармакларында гына белгечләр тарафыннан кулланыла торган сүзләр; ә) әдәби телне баетмый һәм әдәбиятта гомумән очрамый торган җирле сөйләм сүзләре (диалекталь сүзләр); б) тупас сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр; в) хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр; г) ялгызлык исемнәре.

## II. Сүзлекнең төзелеше

§ 7. Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды, һәм алар үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§ 8. Баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелды. Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде, иллюстратив материал китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлде.

§ 9. Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр нокталы калын, ә аларның мәгънәләре җәяле якты гарәп цифрлары белән аерылды.

**ИКМӘК** *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып: – Тәмле! – диде. Икмәк телеме күз ачып йомганчы юкка чыкты.* А.Гыйләҗев ...

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев ...

3) Кырда үсеп утырган иген. *Болгарларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин ...

**2.** *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыйматдинова ...

§ 10. Һәр мәгънә кызыл юлдан башланып китте. Сүзнең якынрак мәгънә төсмерләре параллель сызыклар (//), ә тагы да якын мәгънәләре нокталы өтер (;) ярдәмендә аерып күрсәтелде.

**ӘДӘП** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомум кабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы гадәтләр ... // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү сыйфаты ...

2) Яхшы гадәт, йола ...

**АРКАДАШ** *и.* **1.** Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый ...

§ 11. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар, һәм һәркайсы алфавит тәртибендә үз урынында бирелде.

**АСТРОЛЯБ** *и. гр. сөйл. к.* **астролябия**. *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала*. Н.Исәнбәт

**АСТРОЛЯ́БИЯ** *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы

§ 12. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма һәм тезмә сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде, сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм аңлатылды.

**ӘҖӘ́-ГӨҖӘ КИЛҮ** *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү ...

**ИГЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. а.х.* Ашлык бөртекләрен, зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы:* **головня**

§ 13. Омонимнар шулай ук һәрберсе аерым мөстәкыйль сүзлек берәмлеге итеп алынды һәм якты рим цифрлары белән күрсәтелде.

**БИК** I *и.* 1) *иск. кит. к.* **бәк**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков*

**БИК** II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Сиернең тыныч кына күшәп ятуын ишеткәч, җиңел сулап җибәрә, чолан ишегенең биген тикшерә, өй ишеген «бисмилла» әйтеп яба, аннары түшәген җәеп, ятарга әзерләнә башлый.* И.Гази ...

**БИК** III *рәв.* **1**. 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик еракта, кыр өстендә аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады.* Г.Бәширов ...

## III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аларны аңлату

Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру тәртибе

§ 14. Сүзлектә китерелгән һәр тел берәмлегенең хәзерге әдәби телдә кулланылган барлык мәгънәләре дә аерып күрсәтелде.

§ 15. Алынма сүзләрнең бары тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә китерелде.

§ 16. Күп мәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алынып, аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең бирелеш тәртибе, беренче чиратта, аларның хәзерге әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

ә) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтерлек очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булса да, алдан бирелде. Калган барлык очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң гына теркәлде;

б) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алдарак урнаштырылды;

в) киң кулланыштагы мәгънәләр аның таррак кулланыштагы (гади сөйләм, диалекталь, терминологик һ.б. өчен хас булган) мәгънәләреннән алдарак китерелде;

г) диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчерелмә мәгънәләр туры мәгънәләрдән соң бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең куллану ешлыгы югарырак булганы алданрак китерелде;

ж) сүзнең аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды.

**БА́ЙТАК** *рәв.* **1.** Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы ...

**2.** *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән, дигән сүз.* Ф.Латыйфи ...

**3. байтагы, байтагысы** *и. мәгъ. тартымлы форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев ...

ж) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланылган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

**БӘРАБӘР** *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада кунды.* Дастан ...

**2.** *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит, чыдамлык белән сабырлык фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

**3. бәрабәренә** *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев ...

§ 17. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләрдә ачылган мәгънәләр шул ук мәкалә эчендә төп мәгънәдән соң теркәлде.

**ЕЛДЫРЫМ** *и.* **1.** 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; аҗаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез ул яшен елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар.* А.Хәмидуллин ...

2) *диал.* Яшен. --- *бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады]*. Т.Әйди ...

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов ...

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз сызып, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган ---.* Л.Хәмидуллин ...

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов ...

**2.** *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт ...

§ 18. Сүзнең берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук мәкалә эчендә әйтелгән грамматик формада гомуми кагыйдәләр нигезендә бирелде.

**БАШ** *и.* **1.** 1) ...

21) **башында** *күч. тарт. һәм кыек килеш форм.* Төп җитәкче, оештыручы урынында, башлык дәрәҗәсендә. *Иптәшләр, хәзер җирле граждан эшләре башында торучы Ногматов иптәшкә яшьләрнең регистрацияләре турында хәбәр итү өчен сүз бирелә.* Ф.Бурнаш

**БАГУ** I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. ...

**3**. **бак, ба́ксана** *ы. мәгъ.* «Кара син аны», «кара әле» мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н.Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М.Гали

**4. баксаң, бактың исә** *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бакты исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Баксаң, әле генә китерелгән сан да «соңгы сүз» булмаган икән.* М.Госманов...

§ 19. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар телендә кулланылган мәгънәләренең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

**РАДИА́ТОР** *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне суеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма

Мәгънәләргә аңлатма бирү тәртибе

§ 20. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык гади, кушма һәм тезмә сүзләрнең һәм фразеологик гыйбарәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 21. Аңлатмалар стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр ярдәмендә генә төзелде. Тар кулланылышлы (гади сөйләмгә караган, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.), сирәк очрый торган, искергән сүзләр яки сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре, шулай ук бу сүзлеккә кермәгән сүзләр аңлатмаларда файдаланылмады.

§ 22. Сүзлектә, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аңлатмаларның өч төрле ысулы кулланылды:

1. Тасвирлаулы аңлатма. Сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыкланды.

**ҖАМАЯК** *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү ...

2. Синонимик аңлатма, ягъни сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимын (синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмгә караган һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды.

**ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә ...

3. Башка сүзгә яки аның аерым мәгънәсенә (мәгънәләренә) җибәрү. Бу ысул мәгънәләре охшаш яки бик нык якын булган сүзләрдә (синонимнарда) кулланылды. Төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылды.

**БАЛАШАР** *и. к.* **балимәр**

**БАЛИМӘР** *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан, тонык көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щёткасыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* **медосос**

Күпмәгънәле сүзләргә яки омонимнарга җибәргән очракларда, сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга җибәрелүе күрсәтелде. Искәрмә буларак, сүзлекнең зур күләмле булуын исәпкә алып, икенче сүзнең мәгънәсенә җибәргәндә, ул сүз кергән томның басылып чыккан булу шарты куелды. Бу шартка туры килмәгән очракларда, сүзләр алда күрсәтелгән тәртиптә (нигездә синонимын күрсәтү юлы белән) ачыкланды.

**КАЕРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники ...

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

§ 23. Сүзнең мәгънәсен тулырак ачыклау өчен, кайбер аңлатмаларда кулланылган өстәмә чаралар:

1. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән генә ачылып бетмәсә, аңлатмага өстәп, шул сүзнең синонимнары да китерелде.

**КАЗЫЙ** *и. гар. тар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хәким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен, минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт ...

2. Аерым очракларда бирелгән сүзнең аңлатмасы аның капма-каршы мәгънәдәге сүзләре (антонимнары) белән дә тулыландырылды.

**ҖИҢЕЛЛЕК** *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе:* **авырлык**. *Җисми кагылу түгел, Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем*. Б.Рәхимова ...

2) Уңайлы, җиңел булу: *киресе:* **авырлык, кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль ...

3. Сирәк очракларда, бигрәк тә вариантлары күп булган, төрле сүзлекләрдә төрлечә бирелгән атамаларның русчага тәрҗемәләре дә китерелде.

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ** *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы:* **ряска**

4. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (антонимнар) һәм тәрҗемәләр аңлатма ахырында нокталы өтер белән аерып бирелделәр.

**БАЙЛЫК** *и.* ...

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык, мохтаҗлык**

§ 24. Сүзнең телдә сирәгрәк кулланылган мәгънәләренә сылтамалар биргәндә, ул мәгънә җәя эчендә күрсәтелде.

**ВАФАСЫЗ** *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*) ...

§ 25. Сүзләрнең индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләренә, шулай ук чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр, аерым очракларда, мисалларда гына күрсәтелеп китте.

### IV. Иллюстратив материалны бирү тәртибе

§ 26. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатмалар биргәннән соң, аерым очракларны исәпкә алмаганда, иллюстратив материал белән ныгытып барылды.

§ 27. Иллюстрация өчен китерелгән мисаллар, күбесенчә, татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алынды.

§ 28. Мисалга китерелгән җөмләләр артык озын булган очракта, мәгънәгә зыян китермичә, кыскартулар ясалды. Сүзләр төшеп калган урыннар өч сызыкча (---) белән күрсәтелде:

**ӘБИ́-БАБА(Й)** *җый. и.* 1) ... 2) ...

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан

§ 29. Китерелгән мисаллардагы алмашлык алыштырган сүз, эш-хәрәкәтнең кем тарафыннан башкарылуы, репликаның кемгә төбәлгән булуы яки кем тарафыннан әйтелүе яисә алдагы җөмләләрдән аңлашылган әйтелми калган сүз квадрат җәяләр эчендә искәрмәләр рәвешендә биреп барылды:

**БӘЙЛӘВЕЧ** *и.* 1) Бербөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., изүне, балак очларын һ.б.) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам, дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камалов ...

**БИКЛЕ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса керә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми ...

**ӘЙТЕШҮ** *ф.* 1) ...

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова ...

§ 30. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

§ 31. Аерым очракларда, мисал итеп, сүз тезмәләре яки кыска җөмләләр дә китерелде:

**АБАЙСЫЗ** *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Абайсыз бәреп төшерү*

**БУР** I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый*

### V. Алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү тәртибе

§ 32. Тел хәзинәсендә чит (рус, гарәп, фарсы, фин-угор һ.б.) телләрдән турыдан-туры кучкән алынма сүзләр бар. Алар татар халкының күп гасырлар буена бу халыклар белән якыннан аралашып яшәве нәтиҗәсе булып тора. Борынгы алынмалар, фонетик һәм морфологик үзләшеп, татар теле грамматикасына тулысынча буйсынганнар, аның үз сүзләренә якынайганнар. Хәзерге тел хәлендә бу алынма сүзләрне аерып алу гади кулланучыга мөмкин дә булмас иде.

§ 33. Татар телендә шулай ук европа телләреннән алынган сүзләр дә бар. Алар, нигездә, хәзерге чорда рус теле аша кучкән сүзләр. Сүзлектә мондый сүзләрнең беренчел чыганагы – европа телләре күрсәтелде.

Сүзлек массакүләм белешмәлек булганлыктан, сүз турында мәгълүмат алу өчен, барлык алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү кирәк дип табылды.

### VI. Сүз төркемнәренең бирелеше

§ 34. Сүзлек берәмлеге буларак барлык төр сүз төркемнәре дә алынды. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *а.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ы.* (ымлык), *иярт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§ 35. Исемнәр сүзлектә берлек санда, баш килештә китерелде һәм *и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

§ 36. Җыйма мәгънәдәге парлы исемнәр сүзлек берәмлеге буларак китерелде һәм *җый. и.* грамматик билгесе белән аерымланды:

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ** *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр) ...

2) Сәүдә, сату-алу эше, кәсебе ...

**ӘЙБЕ́Р-КАРА** *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар ...

§ 37. Ялгызлык исемнәренең, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кереп киткәннәре сүзлектә китерелде (**А́МПЕР, ӘБҮҖӘҺЕЛ, ГАЗРАИЛ, ГАЙДАМАК, ГАЙДУК, ДӘҖҖАЛ, ИБЛИС, МА́УЗЕР, ОМ** һ.б.).

§ 38. Урта мәктәп дәреслекләрендә һәм матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләренең исемнәре чикләнгән күләмдә китерелде (**АБХАЗ, АВАР, АВСТРА́ЛИЯЛЕ, А́ВСТРИЯЛЕ, АЗӘРБАЙҖАН, АЛБАН, ӘРМӘН, ӘФГАН, БАЛКАР, БАШКОРТ, БОЛГАР** һ.б.).

§ 39. Исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр (**АВЫРУ, АСРА́У, БЕЛДЕРҮ, ЧӘЧҮ, САТУ, ӘЙДӘҮЧЕ, БИЮЧЕ, ОЕШТЫРУЧЫ, УКУЧЫ** һ.б.), сыйфатлашкан сыйфат фигыль (**ЕЛЛАГАН, ЯРАТКАН** һ.б.), рәвешләшкән хәл фигыльләр (**БАГАНАЛАП, БАЛЛАП, БАТМАНЛАП, ЕЛЛАП, ИПЛӘП** һ.б.) аерым сүзлек мәкаләсе итеп алынды.

§ 40. Алмашлыклар *а.* грамматик билгесе белән аерымланды. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм *ул, бу, шул* алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде:

**МИН** (**минем, миңа, мине, миннән, миндә**) *а.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы

**УЛ** II (**аның, аңа, аны, аннан, анда**) *а.* 1) Өченче затны яисә гомумән предметны белдерә …

2) Исемнәрне ачыклаган сүзне алмаштырып килә торган күрсәтү алмашлыгы; *андый, мондый, шундый…*

**АҢА** *а. Ул* алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

§ 41. Фигыльне сүзлектә бирү формасы итеп, төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы алынды һәм *ф.* грамматик билгесе белән аерымланды: **АЛУ, ӘЙТҮ, ДИМЛӘ́Ү, ЗЫҢЛА́У, КҮЗӘТҮ, КАЙТУ, КӨЛҮ** һ.б.

§ 42. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, шунлыктан алар сүзлектә теркәлмәде.

§ 43. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде:

**АШАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган туй сәдакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөз-кыяфәт, кием-салым һ.б.ш. турында). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе*

*җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары янын-нан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага.* А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашал-ган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

§ 44. Дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, фразео-логизмнарны күрсәтеп бетергәннән соң, беренче сүз прин-цибы белән шул фигыль янында ояда алфавит тәртибендә теркәлде:

**БӘЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) ...

2) ...

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү

**Бәйләп алу** Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу

**Бәйләп ату** Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү

**Бәйләп бару** Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү

**Бәйләп бетерү** Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен төгәлләү

**Бәйләп кую** 1) Алдан бәйләп әзер итү

2) Бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту

**Бәйләп ташлау** Тиз-тиз генә бәйләү

**Бәйләп тору** 1) Булган берсен, һәрберсен бәйләү

2) Сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу

3) Һәрвакыт, гел бәйле итү

**Бәйләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрберсен бәйләү

**Бәйли бару** Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү

**Бәйли башлау** Бәйләргә тотыну

**Бәйли төшү** Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү

§ 45. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясый торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләр (дәрәҗә фигыльләре) кулла-нылды: **алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, ташлау, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту**

§ 46. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грам-матик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә дә аңлатма биргәч, нокталы ярымка-лын гарәп цифрыннан соң, алар аерым күрсәтелеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды:

**ВАКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы так-таларны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М.Мәһдиев

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмашты-ру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гый-ләҗев...

**2**. **ваклап** *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, өлешләп, бүлгәләп. *Фәния кисәк-кисәк ваклап сөйләшә торган теле белән зар-ланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кы-ланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыз-дырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

§ 47. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр яр-дәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде:

**КИТҮ** *ф.* **1.** 1) ... ; 2) ... .

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер исем, сыйфат, рәвешләр белән килеп, шулардан аңлашылган то-рыш, билге һәм рәвешкә күчүне белдерә. *Эшләр уңайга китте. Талашуга киткәч булмый инде ул*

2) Эш-хәлнең кинәт булуын белдерә. *Балкып китте*

3) Эшнең башка бер эш уңаенда кыска гына аралыкта булуын белдерә. *Таныштырып китү. Искә төшереп китү*

4) Эшнең башлануын һәм дәвам итүен белдерә. *Сөйләп китте. Санап китү*

## VII. Сүзнең басымын күрсәтү тәртибе

§ 48. Татар телендә басым, күбесенчә, сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Баш сүз булып килгән мондый очракларга (шул исәптән алынма сүзләргә дә) басым куелмады. Басым башка иҗекләргә төшкән очракларда гына сүзнең басымы күрсәтелде.

**БАТЫРЛА́РЧА** *рәв.* ...

**Ю́ГЫЙСӘ** *тер.*

**ГИГИЕ́НА** *и.* ...

Бу кагыйдә омографларга да карый, әмма басымның кай-да булуына карамастан, чагыштыру һәм дөрес уку өчен, ба-сым икесенә дә куелды.

**А́РКА** *и. лат.* 1) *махс.* Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсә-ләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме)

**АРКА́** *и.* **1.** 1) Кеше гәүдәсендә муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як ...

§ 49. Татар телендә *-а / -ә* сузыкларыннан соң килгән *-у / -ү* авазлары сөйләмдә, кыскарып, ирен-ирен *в [w]* сонанты булып әйтелә, ә төзелмә үзе *[aw] / [əw]* тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә, шул сәбәптән, басым *-а / -ә* сузык-ларына төшә. Бу очрак сүзлектә күрсәтелде.

**АБА́У** *ы.* ...

**АҢКА́У** II *и. анат.* ...

**БИКЛӘ́Ү** I *ф.* ...

**ВАКЛА́У** *ф.* ...

**ДӘ́Ү** *с. фар.* ...

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*анат.* – анатомия
*артык.* – артыклык (дәрәҗәсе)
*археол.* – археология
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*а.х.* – авыл хуҗалыгы
*әд.* – әдәбият термины
*баш. кил.* – баш килеш
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*берл.* – берлек сан
*биол.* – биология
*биохим.* – биохимия
*б-сез.* – билгесезлек
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*вет.* – ветеринария
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геол.* – геология
*геом.* – геометрия
*грам.* – грамматика
*дәр.* – дәрәҗә
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*диңгез.* – диңгезчелек термины
*жарг.* – жаргон
*җый. и.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*зоол.* – зоология
*з.-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*и.* – исем
*икът.* – икътисад
*информ.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*кбт. форм.* – кабатлаулы формада
*кайт. юн.* – кайтым юнәлеше
*карг.* – каргау (каргыш) сүзе
*кер. сүз* – кереш сүз
*кеч.* – кечерәйтү
*кил.* – килеш (формасында)
*ким.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кино* – кинематография
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*комп.* – компьютер
*көч.* – көчәйтү
*кулин.* – кулинария термины
*күпл.* – күплек санда
*күрс.* – күрсәтү
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*метеор.* – метеорология
*минер.* – минералогия
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*мод. ф.* – модаль фигыль
*мөн.* – мөнәсәбәтлек (сүз)
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*неол.* – неологизм
*нәфр.* – нәфрәтләнү
*окказ.* – окказионализм
*пед.* – педагогика
*психол.* – психология
*радио* – радиотехника
*рәв.* – рәвеш
*рәсм.* – рәсми
*ритор.* – риторик
*с.* – сыйфат
*сан* – сан
*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси термин
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләм телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*тар.* – тарихи
*тарт. форм.* – тартымлы формада
*тасв.* – тасвири сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*типогр.* – типография термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*төзел.* – төзелеш термины
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем (юнәлеше)
*туп.* – тупас сүз
*тур.* – турында
*урт. юн.* – уртаклык (юнәлеше)
*у.-вак. кил.* – урын-вакыт килеше
*ф.* – фигыль
*фарм.* – фармацевтика
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия
*финанс.* – финанслар
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында
*фото.* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* – хуплау
*хурл.* – хурлау
*хәб. функ.* – хәбәр функциясендә
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби сүз
*чаг.* – чагыштыру
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шаярт.* – шаярту сүзе
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*ы.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*электр.* – электротехника
*эпис.* – эпистоляр стиль
*этн.* – этнография
*юг.* – югары стиль
*юкл.* – юклык
*юн.* – юнәлеш
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ялг.* – ялгыш куллану варианты
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

## Чыганак телләрнең кыскартылмалары

*алб.* – албан теле
*амхар* – амхар теле
*афр*. – Африка телләре
*әрм.* – әрмән теле
*баконго* – баконго теле
*бурят* – бурят теле
*венг*. – венгр теле
*гар*. – гарәп теле
*герм.* – герман телләре
*голл*. – голланд теле
*гр*. – грек теле
*груз*. – грузин теле
*гуарани* – гуарани теле
*ингл*. – инглиз теле
*исланд* – исланд теле
*исп*. – испан теле
*ит*. – итальян теле
*кельт* – кельт теле
*кечуа* – кечуа индеецлары теле
*коми* – коми теле
*кыт*. – кытай теле
*лат*. – латин теле
*литв.* – литва теле
*малай* – малай теле
*малаял.* – малаялам теле
*мар*. – мари теле
*монг*. – монгол теле
*мордв.* – мордва теле
*нем*. – немец теле
*норв.* – норвегия теле
*пол*. – поляк теле
*полинез*. – полинезия телләре
*португ*. – португал теле
*румын* – румын теле
*рус* – рус теле
*саам* – саам теле
*санскр.* – санскрит теле
*сканд.*– скандинав телләре
*слав.* – славян телләре
*тамил* – тамил теле
*тат.* – татар теле
*төрек* – төрек теле
*төрки* – борынгы төрки сүз
*тунг*. – тунгус теле
*тупи* – тупи теле
*удм.* – удмурт теле
*уйг.* – уйгур теле
*укр*. – украин теле
*үзб.* – үзбәк теле
*фар*. – фарсы теле
*фин* – фин теле
*фин-угор* – фин-угор телләре
*фр*. – француз теле
*һинд.* – һинди теле
*чех*. – чех теле
*швед* – швед теле
*эст*. – эстон теле
*як.*– якут теле
*яп*. – япон теле
*яһүд* – яһүд теле

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Аа** | **Дд** | **Зз** | **Мм** | **Пп** | **Үү** | **Чч** | **ь** |
| **Әә** | **Ее** | **Ии** | **Нн** | **Рр** | **Фф** | **Шш** | **Ээ** |
| **Бб** | **Ёё** | **Йй** | **ң** | **Сс** | **Хх** | **Щщ** | **Юю** |
| **Вв** | **Жж** | **Кк** | **Оо** | **Тт** | **Һһ** | **ъ** | **Яя** |
| **Гг** | **Җҗ** | **Лл** | **Өө** | **Уу** | **Цц** | **Ыы** | |

# С

**СААМ** *и.* Норвегия, Швеция һәм Финляндиянең төньягында, Россиянең Кола ярымутравында яшәүче, фин-угор төркеменә караган телдә сөйләшүче аз-санлы халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Саам әкиятләре*

**САБА** I *и. иск.* Су, кымыз кебек сыеклыклар салып йөртелә торган капчык шикелле тире яки күн савыт; турсык, күнәк. *Сакалына күрә эскәге, сабасына күрә пешкәге.* Мәкаль. *Ул үзе яки энесе атнага бер-ике тапкыр Троицкига чәйшикәр, икмәк алырга кайтып киләләр, итнең яңа суелганын, тәмлесен мул итеп ашыйлар, кымызны ашыкмыйча гына, каймак тәмнәре кергәнче ысланган сабада озак шапырып, агач аякларда эчәләр.* А.Расих. *Исәнтәйгә ул, буза салынган сабаны алып, үзе янынарак кученеп утырырга кушты.* Н.Фәттах

**САБА** II *и. гар. шигъ.* Иртән көньяктан исә торган саф, йомшак җил; зефир, нәсим. *Әгәр барсаң, саба җил, безнең илгә, Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!..* Дәрдемәнд. *Әкрен генә искән саба җиле битләрне сөеп китте.* М.Гафури. *Ниләр җитмидер күңелгә – Саба җилләре микән?* Ш.Җиһангирова

**САБАК** I *и. бот.* 1) Үлән үсемлекләрнең тамырдан алып очына кадәрге яфраклар, бөреләр һәм чәчәкләр чыгара торган үзәк өлеше. *Коры камыш сабакларын сындырып, алар куерак, куркынычсызрак урыннарга омтылдылар.* Н.Фәттах. *Бәрәңге сабагы яндырганда чыккан төтен бөтенләй үзгә ул!* Р.Зәйдулла

2) *диал.* Ботак. *Көн аяз һәм чатлама салкын булды. Агач сабакларына, телеграф чыбыкларына бәс каткан иде.* А.Расих. *Көзгә таба аның кып-кызыл миләш сабаклары кызыл ахак кеби салынып, сөялеп, яшь кызларның муенына, кулыны, колагыны бизәкли торган төймәләр, алкалар кеби, Сөннәтче бабайның өене бизи иде.* Г.Исхакый

3) *диал.* Йөгән, нукта кебекләрнең кулга тотыла торган өлеше; тезген. *[Садыйк] Кече капкадан аты-ние белән килеп кергән Солтанның йөгереп каршысына килде, атны йөгән сабагыннан эләктереп алды.* Г.Ахунов. *Йөгән сабагын дугага күтәреп бәйләгән арада мыгырданды [Борһан].* М.Мәһдиев

**САБАК** II *и. гар.* 1) Уку сәгате; дәрес (гадәттә элекке мәктәп-мәдрәсә дәресе тур.). *Тиздән сабак башлана дип, Тавыш килә мәктәптән.* М.Гафури. *Нажҗия аның әтисен башкалар белән бергә, көн саен балалар сабакка җыелган чакны туры китереп, мәктәп тирәли йөгертеп кенә калмый, башка руханилар белән бергә салкын баракта асрый.* Г.Ахунов // Гомумән, уку-укыту. *...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез.* Ә.Еники. *Имеш, алар абыстай өенә сабакка йөрсәләр дә, хәреф танырга гына өйрәнгәннәр, яза белмәгәннәр.* Р.Зәйдулла. *Сабакка бару. Сабакка бирү. Сабактан туктау*

2) Укыла торган дәрес, фән, алынасы белем (элекке мәктәп-мәдрәсә дәресе турында, шулай ук өлкәннәр телендә). *Ул безне урыс сабагына өйрәтте.* М.Мәһдиев. *Ишетсен колагыгыз, сабагыгызны тырышып укыгыз, минем йөземә кызыллык китермәгез.* Г.Галиева // Өй эше, өйдә яки дәрестән тыш үтәлергә тиешле бирем. *Кулыңа ал сабагыңны, Булган бит сәгать сигез.* М.Гафури. *Утызлап бала арасында чайкала-тирбәлә лыбыр-лыбыр сабак ятлап утырган Баязитка карата ул әле хәтта таләпчәнрәк тә булды.* Г.Минский

3) *күч.* Киләчәктә кабатлануыннан тыйган күңелсез вакыйга, уйланырга мәҗбүр итә торган хәл; гыйбрәт, ачы тәҗрибә. *Ул аны бүтәннәргә сабак булсын өчен эшләгән!* Н.Фәттах. *Аларның исә, демократик кыйммәтләр турында сөйләнгән хәлдә, власть вертикален тәгаен игълан итүләре бик күп кешеләргә тарихи сабакны, репрессив ысулларны искә төшерде.* Р.Зәйдулла

◊ **Сабак алу** 1) *иск.* Дәрес тыңлау, белем алу, уку. – *Сабакны мин Көнбаш атакайдан алдым, – диде унбаш. – Ләкин, риза булса, бу җен карчыгыннан да сабак алыр идем.* М.Хәбибуллин. *Гимназиядә бертөрле сабак алса, Галимҗан Алмабикәгә әллә күпме әдәбият, сәнгать буенча «дәрес» бирә.* С.Поварисов; 2) Күңелсез эш-хәлдән, гыйбрәтле вакыйгадан киләчәк өчен файдалы нәтиҗә ясау. *Тик ул моннан үзенә сабак алмады.* Г.Ахунов. – *Килдебеков, тиешле сабак алгансыңдыр дип уйлыйм, – диде капитан.* Р.Зәйдулла. **Сабак баласы** *иск.* Уку яшендәге бала. *Кайдадыр шүрлек почмагында озак вакытлар кузгалмый тузан җыеп яткан Коръәннең ике як тышлыгын да, сабак баласыдай тырышлык күрсәтеп, ялап-ялап алды.* Ф.Хөсни. **Сабак бирү** 1) *иск.* Укыту, дәрес бирү яки өй эшен эшләтү (элекке мәктәп-мәдрәсәләрдә). *Троицк мәдрәсәсендә шәкертләргә дин тарихы, Коръәнне мәкам белән уку, хисап буенча сабак биргәндә телгегенә ирешә ул [Галимҗанның әтисе].* С.Поварисов; 2) Киләчәктә игътибарлы, сак булыр өчен җәза бирү, каты тәнкыйтьләү һ.б.ш. *Сиңа актив җыелышы биргән сабак аз булган, күрәсең.* Р.Ишморат. *Беләбез бит инде, ничә кабат Тарих бирде сабак, ниһаять: Кайсы гына менеп утырса да, Җинаятьче улы Җинаять!* М.Әгъләмов. **Сабак өе** *иск.* Хосусый мәктәп. **Сабак өйрәтү** *к.* **сабак бирү**. **Сабак тыңлату** Укытучы-хәлфәдән алган сабакны укучы-шәкерттән кабатлатып, сөйләтеп тикшерү (элекке мәктәп-мәдрәсәләрдә). *Шуннан соң ул өскә менеп чәй эчеп төшә дә, һәйбәт сабын исләре килеп торган матур кулларын берсе өстенә*

*икенчесен куеп, биш-алты баланың сабагын тыңлата да кузгалып китә.* Г.Бәширов. *Көн саен бер мәртәбә сабак тыңлатып, матур язу дәресе үткәргәннән соң, әтисе аңар Тукайның берәр шигырен ятларга куша.* Г.Ахунов. **Сабак тыңлау** Дәрес алу, укытучы сөйләгәнне тыңлап утыру. **Сабак уку** *к.* **сабак алу** (*1 мәгъ.*). *Гайникамал – остабикәдә сабак укучы кыз.* Т.Гыйззәт. *Баянов Буби мәдрәсәсендә чакта Габбас мулладан сабак укыган икән.* Г.Ахунов. **Сабак укыту** *к.* **сабак бирү** (*1 мәгъ.*). *Нуриягә нинди сабак укыту турысында да әтисе белән әнисе уртак тел таба алмадылар.* Г.Ахунов. *Сәясәтчеләр мәктәпләрдә «Патриотик тәрбия дәресләре» кертү турында сөйли башлады. Ышанам, укытачаклар андый сабакны да...* Р.Зәйдулла

**САБАКЛАНУ** *ф. бот.* Сабак үстерү, сабак чыгару, үсемлекнең сабагы барлыкка килү

**Сабаклана бару** Торган саен сабагы ныграк үсү

**Сабаклана башлау** Сабакланырга тотыну

**Сабакланып бетү** Сабагы тәмам үсеп җитү

**Сабакланып килү** Сабагы үсә башлау

**САБАКТАШ** *и.* Бергә сабакка йөргән, бергә укыган кеше; шәрик. *Эзләреңнән синең, сабакташым, Алма-Атага барган идем былтыр, Торган җирләреңне табыйм дип.* Х.Туфан. *Ә Саяра үзе, көнчелегеннән, сабакташы Назирәне хәтта күралмый башлады инде.* Г.Галиева

**САБАКТАШЛЫК** *и.* Сабакташ булу

**САБАКЧА** *и. бот.* Үзәк сабактан тармакланып аерылып чыккан кечкенә сабак

**САБАЛЬ** *и. лат. бот.* Пальмалар семьялыгыннан Америкада үсә торган җилпәзәсыман пальма

**САБАН** *и.* **1.** 1) Киң тимер төрәне һәм махсус калагы булган җир сөрә торган авыл хуҗалыгы коралы; камилләштерелгән сука. *Ә мескен Хәйрулланың Әбугалисинага тиң газиз улы, урысча белмәгәнгә күрә, һаман баткак бораздада сабан артыннан сөйрәлеп йөри.* М.Юныс. *Бер кулы белән сабан руленә тотынган Хөсәенов бураздадан бер уч туфрак алып яңакларына тидерде.* Р.Йосыпова

2) Җирне сөреп эшкәртү эше. *Аның күңеле төшенке, эшкә кулы бармый, сабанга чыгарга кирәкле ат тырмасының коелган тешләрен кагарга кирәк булгач та бик ыңгырашып кына тотынды.* Г.Ахунов. *Ир-атлар сабанда арган атларын тәрбияләү, тарантас, ат сбруйларын тәртипкә китерү белән мәшгульләр.* Г.Галиева

3) Язгы сөрү-чәчү эшләре. *Җәй башында һәр көн, сабан беткәч, Ак каенда бәйрәм ясыйлар.* З.Ярмәки. *– Сабан алдыннан ниткән ат алҗытып йөрү ул? – Картның төсе качты. – Кем кушты сиңа?* Г.Ахунов. *Язгы сабаннарга әллә колхозчыларны җигәрме прсидәтел иптәш?* Н.Гыйматдинова

4) Язгы сөрү-чәчү вакыты, чоры. *Сайрап чыга тургай сабанда.* Ш.Маннур. *Гаспадиннар, кызганыгыз. Ул бит буаз. Сабан җитә, ул бит буаз.* Г.Ахунов

5) Яз чәчелеп, шул ук елны өлгерә торган иген, берьеллык иген; *русчасы:* **яровые**. *Аурышкан як басуда сабанмыни?..* Г.Бәширов. *Ул игеннәрнең уңуы дисеңме: арыш арасында адашырлык, сабан ашлык арасында дуга күмелерлек.* А.Гыйләҗев. *Гафият авылны чабып узды да сабан басуына килеп чыкты.* И.Гази

6) Кар җыештыру машинасының җир сөрү коралына охшаган җайланмасы. *Кар сабаны*

**2.** *с. мәгъ.* Яз чәчелеп, шул елны өлгерә торган. *Читтән караганда никадәр кечкенә генә төсле күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлык кыры, суга якын йире печәнлеккә бүленгәнгә, башка – урта йире шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрене дә эченә ала алган иде.* Г.Исхакый. *Арыш урагы ике дисәтинә [урдык], сабан ашлык, җитен...* Ә.Фәйзи

◊ **Сабан ае** *иск.* Язгы сөрү-сукалау вакыты. *Сабан аеның беренче көннәрендә, 21 апрельдән башлап, Идел – Урал – Себер төбәкләре төркиләре – татар-башкортлар – Сабан туен, язгы кыр эшләре башлануны бәйрәм иткәннәр.* Р.Сафин. **Сабанга керү** Яше җитеп, сабанга җигелә башлау (эш хайваны тур.). *Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр.* Г.Ибраһимов. **Сабан сөрү** Сабан белән эшләү, җир сөрү. *Үгез гомере буе сабан сөрә, ник сөргәнен белми.* Мәкаль. *Бервакытны шулай сабан өсте, Кырда бергә сабан сөрәбез...* Һ.Такташ. *Язын сабан сөрде, муенына тубал асып, сөргән җиргә ашлык чәчте, печән өстендә печән чапты, кибән куйды, урак өстендә ашлык сукты, эскерт өйде, кышын балык тоту бригадасында катып-калҗаеп боз тиште, җылым тартты.* Д.Каюмова

**САБАНДАШ** *и.* Җирләрен бер үк сабан белән, бергәләп эшкәртүче берничә хуҗаның һәрберсе. *Бу ел без күршеләр белән сабандаш булган идек. Безнең бер ат, аларның өч ат, көйсез агач сабанны шул дүрт ат көчкә генә тарталар.* М.Гафури. *Күк елга авылының Сәйфетдин агай бай кеше түгел иде: кечкенә бер җирән аты, бер кәҗәсе булып, үзе билгән --- җиренең кешеләргә сатылмый калган өлешенә, я сабандаш булып, я яллап сөрдереп, ел саен бер дисәтинә чамасы гына иген чәчә иде.* Г.Рәфикый

**САБА́Н ТУЕ** *и.* Татар халкының язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң үткәрелә торган традицион милли бәйрәме. *Авылның элек-электән Сабан туйлары, җыеннары уза торган урынга килеп җитүгә, мондагы гаҗәеп гүзәллекне күреп өнсез калды Маһирә.* Г.Галиева. *Шушы улы күрәшкәнне карар өчен бит инде, ел саен Фәния, бер ярты сәгатькә генә Исмәгданны ялгыз калдырып, Сабан туе мәйданына йөгереп барып кайта.* Р.Йосыпова

**САБАНТУЙ** *и. к.* **Сабан туе**. *Котлызаман яшьлектә Сабантуйларда гел мәйдан тоткан.* С.Поварисов. *Ташлытауда иртәгә сабантуй буласы иде.* М.Мәһдиев. *Сабантуйлар безнең янда уза иде.* Н.Гыйматдинова

**САБА́Н ТУРГАЕ** *и. к.* **тургай** (*1 мәгъ.*). *[Галимҗан] Зәңгәр күккә*

*бакты. Анда сабан тургае сайрый.* С.Поварисов. *Сиңа атап гүя мәңгелек дан җырлый Аяз күктә сабан тургаең.* М.Гобәйдуллин

**САБАНЧЫ** *и.* **1.** Сабан белән җир сөрүче. *Кара карга кар куа, – Кара җирләр калкуга, Сабанчы белән бергә Төшә дә җылы җиргә Ул атлап йөри ипләп, Төрле кортларны чүпләп.* Н.Арсланов. *Гыйлаҗи сабан арты торткан, Фазыйл белән мин төпкә, Гали очка җигелгән, Шаһбаз, нәкъ сабанчы малайлар кебек, көйләп-көйләп, «атлар» куа иде.* Г.Ибраһимов // *махс.* Трактор белән сөргәндә: сабаннарны көйләп-күзәтеп баручы, шулар өчен җаваплы кеше; *русчасы*: **плугарь**. *Мин сабанчы булып эшлим.* Б.Ислам

**2.** *с. мәгъ.* Сабанга җигелә торган. *Бөкре Гафият кола бия белән сабанчы күк турының бурабзар ишекләрен түбәтәй чаклы йозак белән бикләп куйды.* Г.Ахунов

**САБАХ** *и. гар.* Көннең башы, көннең тәүге сәгатьләре, иртә. *Август аеның рәүшан бер көнендә сабах вакытларында «Н» авылында һич хәрәкәт күрелмәеп, сөкүнәт кәмал дәрәҗәсендә иде.* М.Акъегетзадә. *Шунда мендем дә, иртәнге – сабах намазымны укып, тәпәлисе печәнне тәпәләп бетердем.* А.Хәлим

**САБА́Х-ШАМ** *рәв. фар. иск.* Иртәкич. *Бәнем ядымда бу ахшам сабахшам.* Г.Тукай

**САБИТ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Сүзендә, мәсләгендә һ.б.ш.ларда нык торган, тайпылмаучан, кире кайтмаучан. *Хәвефсез мәсләкемдә сабит улмак Каһарман намыны алганнан артык.* М.Гафури. *Сезең әүлядыңыз сездәй әдәпсез, Әдәпсезлектә сабит сез, әбәд сез.* Г.Тукай // Башкарган эшендә, хезмәт урынында нык, какшамас булган, алып ташларлык булмаган. *Сабит булып шаһлыгында Торна бик күп тормады.* М.Гафури

2) Дәлилләнгән, исбат ителгән. *Без яшьләремезне Бохарага җибәрсәк – ишәк, Истанбулга җибәрсәк – полицейский вә шпион булып кайтачаклары моңгарчы кайтканнары илә сабит вә мөдәлләлдер.* Г.Тукай

**2.** *хәб. мәгъ.* Нык, көчле, какшамас

**САБО** *и. фр.* Агачтан уеп ясалган яки агач олтанлы башмак // Гомумән, шундый башмакка охшаган аяк киеме. *Тек-тек атлап бер кыз килә, аягында – саболар, кич клубтан кайткан чакта, кемнәр аны сагалар?..* Татарстан яшьләре

**САБОТАЖ** *и. фр.* Ниндидер максат белән эшне махсус тоткарлау яки эшкә астыртын зыян салу; эш ташлау, корткычлык. *Конференция вакытында саботаж чыгарырга тиешле яшьләр, чыгыш ясаучының сүзләре белән мавыгып китеп, тәмам телсез калдылар.* Ф.Яхин. *Бу саботаж, иптәшләр!* Р.Батулла

**САБОТАЖЛЫК** *и.* Саботаж ясау; эшне өзү, карарларны үтәмәү күренеше; корткычлык. *Алпавыт, саботажлык кылып, җирне чәчми калдырмакчы, халыкны ачлык белән буып алмакчы булган.* М.Шабай. *Баязитов – егерме елга якын хәреф җыючы булып эшләгән кеше – типографиянең саботажлык итүче иске мөдире урынына яңарак кына мөдир итеп куелды.* И.Гази

**САБОТА́ЖНИК** *и. рус сөйл. к.* **саботажчы**. *Шуны теге саботажникның башына кигердем.* Н.Әхмәдиев. *Мин аларны – саботажникларны – нишләтергә белермен!* Г.Гәрәева

**САБОТАЖЧЫ** *и.* Саботаж оештыручы яки саботажда катнашучы. *Революция елларында Гуревич саботажчылар сафында булды.* А.Алиш. *Калган чиновниклар – министрларның хәтсезе – бюрократия ишкән булып кылана, ишкәкне, суга батырмыйча, һавада гына алга-артка селки. Саботажчылар, ришвәтчеләр һәм каракълар.* Ватаным Татарстан

**САБУ** I *ф.* Киеменең тузган берәр өлешен төзәтү, яңа материал тегеп яки бәйләп кую. *Ул тузган оек яки бияләй кебек киемнәргә баш сабарга өйрәнеп алды.* М.Әмир. *Күн итеккә яңа баш сабу* // Аяк киеме, бияләй башы, өс киеменең якасы кебек өлешләренә икенче төсле яки бүтән төрле материалны тегеп, беркетеп кую. *Саурый читек, чуклы башмак, вак-вак атлап яндыра; Яка сапкан, энҗе таккан, бак, үзен зурга [куя].* М.Укмасый. *Аның тез астыннан бау белән буып бәйләгән тула кунычлы, күн сапкан итекләре дә татар кешесе булмавын күрсәтеп тора иде.* А.Расих

**Сабып алу** Кыска гына вакыт эчендә сабу

**Сабып кую** Алдан сабу эшен төгәлләү

**Сабып ташлау** Тиз арада сабу

**САБУ** II *ф.* 1) Узарга мөмкинлек биреп, читкә чыгу. *Аның артыннан сүз сөйләүче «олуг коммунистлар» Сталинның башлап җибәргән русчылык эзеннән сапмадылар.* Г.Исхакый. *Башкалар, кысрыклана төшеп, сиңа юл сабачаклар, һәм син маргарин түгел, химиясез генә алынган акмай ашаячаксың...* А.Тимергалин

2) Ялгышып, адашып читкә чыгу (юлдан). *Ул, адашып юлдан сапкан вә кайда барырга белми аптыраган кебек, як-ягына карана, өйгә якын бара, берәр тавыш ишетелмәсме дип тыңлап тора.* Ш.Камал. *Урманда сукмактан сабу. Буранда юлдан сабу*

3) *сир.* Язу (акылдан). *Гакылымнан тәмам саптым.* Г.Кандалый. *Монда Исак үзалдына, кеше саен, акылдан сапкан кешечә җикеренеп йөри, кеше саен бәйләнә.* Ш.Камал

**Сабып бетү** Тәмам сабу

**Сабып тору** Вакытлыча сабу. *Ә урман заданиесен үтәп, расчётлар алып, авылларга таралышкан кичне теге егет, нәкъ шулай выжылдап узганда, карга кереп юл сабып торган Зөлхәбирәне чанасына төртеп еккан да авылларына алып киткән.* М.Мәһдиев

**САБУ** III *ф. диал. к.* **сабышу** (*1, 3 мәгъ.*). *Миңнулла абзагыз тәмам авыруга сапты.* И.Гази. *Хода күрсәтмәсен байларның елкы ите ашап бирәнгә сабуын.* Ш.Мөхәммәдев. – *Харап булдык, Шәүкәт абый сиңа язган хатымны бөтен кеше алдында укып, алтыннарны кайдан алуымны сорады, – дип, мәктәптә булган хәлләрне җиткерде ул хатына, авыруга сапкан кешедәй хәлсез ыңгырашып.* Ш.Алпар

**САБЫЙ** *с. гар.* **1.** 1) Бик яшь, кечкенә (балалар тур.). *Сабый бала кебек, ул ни әйтсәң дә каршы килмәс, нәрсә әйтсәң дә берсүзсез ышаныр төсле*

*иде.* Н.Фәттах. *Әткәй, әнкәй өчен бала Һәрчак сабый булып кала.* Г.Юнысова

2) Сабыйларныкы төсле (чырай, кыяфәт һ.б.ш. тур.). *Калын гәүдәле, кара сакаллы профессор бәләкәй куллары белән корсагын яшерергә азапланып утырган Нуриягә, аның --- калынаеп, күпереп киткән сабый иреннәренә бигүк төбәп карарга базмыйча, иплән кенә: – Студентка Уразаева, ирегез кем? – дип сорады.* Г.Ахунов. *[Кытайларның] Беришеләре, бигрәк тә кеп-кечкенә сабый аяклы хатыннары, төрле төстәге махсус кәгазьләрдән чәчәкләр һәм башка бик матур әкәмәт нәрсәләр ясап саттылар.* Ә.Еники. *Һашимов сабый күзләре белән булачак бабасына сокланулы караш ташлады.* Р.Зәйдулла

3) Балалык елларына туры килә торган (чор, вакыт һ.б.ш. тур.). *Нинди ваемсыз, нинди рәхәт булган ул сабый чак!* Г.Бәширов. *Ул шушында, шушы өйдә туган һәм үткәргән сабый еллары н.* Ш.Маннур

4) Яңа үсеп чыккан, яфрак ярган, ачылган (чәчәк, бөре, яшь агач үсентеләре тур.). *Ник яшь түгә сабый таллар, Дулкыннарга иелеп-иелеп?* Ш.Таһирова. *Бакчаларың, Казан, яфрак яра. Һәр яфрагың шундый өр-яңа! – Бу дөньяданиләр бар? – дигәндәй, Сабый чәчкәң безгә елмая.* Х.Туфан

5) *күч.* Мәсьәләнең асылын аңламаучы, беркатлы кеше. *Әллә ул мине политикада бөтенләй сабый дип уйладымы?* И.Гази. *Соңгы могиканнар болар, диде Безне кайбер полит сабыйлар.* Х.Туфан

**2.** *и. мәгъ.* Бәби, кечкенә бала. *Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята – я, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?..* Ә.Еники. *Гөнаһсыз сабыйның шулай онытылып көлүен Маһирә челтерәп аккан чишмә тавышына тиңләде.* Г.Галиева

**САБЫЙЛАНУ** *ф.* 1) Кечкенә балалар кебек кылану. – *Тын гына утыр! Сабыйланма! – дип тупасланды Васфия.* М.Хуҗин. *Сабыйланма әле, зинһар, дип, кырыс кына бүлдерде аны Бугров.* М.Зарипов

2) Сабыйларга охшау

**Сабыйлана башлау** Сабыйлык билгеләре барлыкка килү. *Картайган саен сабыйлана башлыйсың, диләр бит.* Шәһри Казан

**Сабыйланып алу** Кыска бер вакытка кечкенә балалар кебек кылану

**Сабыйланып калу** Кинәт ниндидер кичерештән соң сабый балага охшый башлау. *Куанычыннан Габделбәрнең күзләре яшьләнде. Алай гына да түгел, тәмам сабыйланып калды ул.* М.Шабай

**Сабыйланып тору** Хәзерге моментта сабый балалар кебек кылану

**САБЫЙЛЫК** *и.* 1) Сабый булу; шуңа хас сыйфатлар. *Сабыйлык дип әйтү килешмәс, малайлык чыгып бетмәгән иде шул әле үзләреннән.* Р.Мөхәммәдиев. *Менә шул сабыйлыгым чыгып җитмәгәнгә, ахрысы, күз алдымдагы манзара-күренешләр дә өзек-өзек, кисәк-кисәк кенә сакланган.* А.Хәлим

2) Сабый чак, балалык. *Сабыйлыгым инде күптән үткән, Егет чаклар бара онытылып.* С.Урайский. *Сабыйлык дәвере илаһи бер күренеш шикелле узып китә.* Г.Ибраһимов. *Әнә Дилә апагыз... Мескенкәйне сабыйлыгында кирәгенчә тәрбияли алмадык шул.* А.Гыйләҗев

3) Сабый бала кыланышы, өлкән кешегә хас булмаган эш, сүз һ.б.ш. *Бу сабыйлыгымны шушы көнгә тикле берәүгә дә сөйләгәнем юк иде әле, актык сүзләремне әйттерәсең.* Р.Төхфәтуллин. *Аннары алар бер-берсенә сыенып, яшьлекнең эчкерсез сафлыгы һәм ышанучан сабыйлыгы белән кушылган тойгыларыннан башлары әйләнеп, исереп, дөньяларын онытып утырдылар.* Г.Ахунов

**САБЫ́Й ЧАК** *и.* Сабыйлык, балалык, бала чак. *Яшел аланнары – чиккән юрган. Сабый чагым әллә шунда калган.* Г.Зәйнашева. *Шул бәпкәләрдәй сабый чагымны Әнкәем кабат искә төшерде.* В.Казыйханов. *Сабый чактан күңелләргә кергән Әнкәемнең моңлы тавышы.* В.Илембәтов

**САБЫН** *и. гар.* Төрле майлар белән селтеләр катнашмасыннан ясала, суда эреп күбекләнә һәм юу-юыну өчен тотыла торган матдә. *Кулыңны башта «Гөлҗиһан» сабыны белән ю!* М.Мәһдиев. *Кыш буе келәттә яткызган олау-олау сабынын сигез-тугыз авылдагы кибетенә бүлеп биреп, бәясен икеләтә арттырды [Таминдар бай].* Г.Ахунов

**САБЫ́Н АГАЧЫ** *и. бот.* Сапидчалар семьялыгыннан Азия һәм Америка тропикларында үсә торган мәңгеяшел агач; сапиндус

**САБЫНЛА́У** *ф.* Сабын сөртү, сабын белән ышку; сабын сеңдерү. *Очучыңа, пират-йолкышыңа Маршрутлар биргән кулыңны Сабынлап ю, Аденхауэр исе – Фетнә исе килгән кулыңны.* Х.Туфан. *Газ булыр дип иске подвалларга төшми, белмәгән җирдә су эчми, үзләренең ишек тоткасына кагылса да кулын кат-кат сабынлап юа иде.* А.Гыйләҗев. *Мунчаланы сабынлау. Тәнне берничә тапкыр сабынлау*

**Сабынлап алу** Тиз арада сабынлау

**Сабынлап бетерү** Тәмам бөтен нәрсәне яки бөтен җирне сабынлау

**Сабынлап кую** Сабын сеңдереп калдыру. *Икебезгә бер бау сабынлап куелган инде.* Р.Мирхәйдәров

**Сабынлап чыгу** Рәттән, тоташ сабынлау

**САБЫНЛЫ** *с.* 1) Сабыны булган, сабын катнаштырылган, составында сабын булган. *Нурдидә ханым, һәр кичтәге гадәтенчә, ишек тоткаларын, бусагаларны сабынлы су белән юарга керешкәч, бүлмәдә бик таныш авазлар яңгырады.* А.Гыйләҗев. *Әлбәттә, бу – эш инде, ләкин мин кулларыма карыйм: кайнар, сабынлы суда бер дә бозасым килми шул үзләрен...* Ә.Еники

2) Сабынланган, сабын сөртелгән. *Кая барырга белми шашып калган сабын кайнатучылар, ни эшләүләрен аңламастан, ут капкан сабынлы киемнәрен сүндерергә тырышып, цех буенча йөгерешергә тотындылар.* А.Расих. *Сабынлы мунчала. Сабынлы кул*

**САБЫ́Н ТАШЫ** *и. мин.* Яшькелт яки ак төсле, тотып карауга майлы кебек минерал, талькның бер төре

**САБЫ́Н ҮЛӘНЕ** *и. бот.* 1) Канәферчәләр семьялыгыннан су буйларында, тугайларда үсә, медицинада, кулинариядә кулланыла торган ак, сирәгрәк ал чәчәкле күпьеллык үсемлек; нугай сабыны; *русчасы:* **мыльнянка**

2) Канәферчәләр семьялыгыннан урманда, әрәмәлекләрдә үсә торган кыпкызыл чәчәкле күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **зорька**

3) Канәферчәләр семьялыгыннан дымлы болыннарда, ачык урманнарда үсә торган ал, ак чәчәкле, сабагында селәгәйгә охшаш күбек була торган күпьеллык үсемлек; күке үләне, күке сабыны; *русчасы:* **кукушкин цвет**

**САБЫН ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* 1) *к.* **сабын үләне** (*2 мәгъ.*)

2) *к.* **сабын үләне** (*3 мәгъ.*)

**САБЫНЧЫ** *и.* Сабын эшләп чыгаручы яки шуның белән сәүдә итүче. *Сабынчы Муса агай күп еллардан бирле сабын эшләп, ун вә унбиш мең тәңкә акча ясаган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Шәхми бабайча: Тфү! Сабынчы марҗалар!* Һ.Такташ

**САБЫНЧЫЛЫК** *и.* Сабын җитештерү эше

**САБЫР** I *с. гар.* **1.** 1) Түзем һәм тыныч холыклы; ашыкмаучан, ашкынмаучан. *Зәкия япь-яшь булса да, бик сак, сабыр кыз булып чыкты.* Г.Галиева. *Шулай да хат ташучы Хәдичә апалары сабыр кеше иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Элек тыныч иде, сабыр иде [Хәлимнең әнисе], йортка килен кергәч, холкы үзгәрде дә куйды, Ходайның хикмәте.* Р.Зәйдулла

2) Сабырлыкны чагылдыра торган (рухи хәл, мөгамәлә һ.б.ш. тур.). *Тап төшмәсен сезнең нурлы, Сабыр йөзләргә.* Х.Туфан. *Менә шушы ягымлы, сабыр тавыш мине тәшвишләнүдән уятты, һәм мин Галимҗан аганың сорауларын хәтерләдем.* И.Салахов. *Кайчан күрде соң ул сабыр, моңсу карашлы соры күзләрне?* Р.Зәйдулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сабырлык белән. *Олуг каһин сорау бирүчегә сабыр гына җавап бирде.* М.Хәбибуллин. *– Мондый нәтиҗә ясарга һич урын юк әле, Габдулла, – диде Хөсәен сабыр гына.* А.Расих

2) Үз-үзен кулда тота алып, түземлелек саклап. *Иәләшер өчен, шактый вакыт кирәк булды. Комсызланмады ул. Сабыр тотты үзен.* С.Поварисов. *Ул баскычтан салмак адымнары белән сабыр гына төште дә иң кара күренгән тыкрык ягына юл алды.* К.Тимбикова

**3.** *и. мәгъ.* Сабырлык. *Мин үз-үземә инде бөтен сабырымны җуям шикелле тоела башлады.* Ф.Әмирхан. *Җитәр, йөрәк, сабыр кирәк, Ташла януларыңны.* Х.Туфан. *Тик торырлык, тукталып көтәрлек сабыры калмаган иде инде аның.* К.Тимбикова

◊ **Сабыр казаны шартлау** *к.* **сабыры төкәнү**. *Буржуйларның шартлады сабыр казаны.* Г.Камал. **Сабыр канаты сыну** *к.* **сабыры төкәнү**. *Ялгыз торып, тәкатем корыды. Сабыр канатларым сынды. Гомер буе ялгыз ябалак булып интегәсем килми.* А.Гыйләҗев. *Иртәгә бюро дигән көнне Шәяхмәтнең сабыр канаты сынды.* М.Мәһдиев. **Сабыр касәсе тулып ташу** *к.* **сабыры төкәнү**. *Инде буаз танасы да эт авызына эләккәч, хуҗаның сабыр касәсе тулып ташты.* Н.Гыйматдинова. **Сабыр күле кибү** *к.* **сабыры төкәнү**. *Сабыр күлем кибеп, үзебезнең тыкрыкка менсәм, Илгизәр сыерларның ике мөгезенә дә асылынган, күзләрен елтыратып мине көтә икән.* Н.Гыйматдинова. **Сабыры сабыннан ычкыну** *к.* **сабыры төкәнү**. *Шәңгәрәйнең мондый җавабыннан соң, картның да сабыры сабыннан ычкынды, Габделкадыйр бабагыз таягы белән идәнгә төрткәли башлады.* И.Гази. **Сабыр савыты тулу (ташу)** *к.* **сабыры төкәнү**. *Бүген ул әчендә яшәгән тормышның артык тарлыгын, артык кысанлыгын бигрәк ачык тойды: шул гади вакыйга сабыр савытын ташыттырды.* Г.Ибраһимов. *Син бит Сылубикәне дә, авылда иң сабыр хатын, дия идең. Аның да сабыр савыты тулып ашкандыр, җанашым.* Г.Галиева. *Мәрьямбикәнең сабыр савыты тәмам тулды, аның үз-үзе белән әңгәмәсен сүзсез үкерү алыштырды.* А.Әхмәтгалиева. **Сабыры төкәнү** Түземлеге, сабырлыгы бетү. *Гомеремдә апаңа авыр сүз әйткәнем юк иде, бу юлы сабырым төкәнде, сүгенеп ташладым...* А.Гыйләҗев. **Сабыры шартлау** *к.* **сабыры төкәнү**. *Гел-гел сабыр итмәс бит ул, сабыры шартлар бит.* М.Әмир

**САБЫР** II *и. гар. махс.* Медицинада: киптерелгән хәлендә йомшарткыч итеп кулланыла торган алоэ яфракларының куертылган суы. *Сабыр порошогы. Сабырның суда эрүе*

**САБЫРАЮ** *ф. сир. к.* **сабырлану**

**Сабыраеп китү** Соңгы вакытта сабыраю. *Бүгенге Гөлфая без белә торган Гөлфая түгел иде инде. Ничектер сабыраеп киткән, йөзендә, күз карашында моңсулык һәм нindидер эчке борчылу ярылып ята.* Г.Әпсәләмов

**САБЫ́Р ИТҮ** *ф.* Нindидер үзгәрешләр яки нәтиҗәләрне түзем генә көтү, чыдап тору. *Сабыр иткән – морадына җиткән.* Мәкаль. *Үтте еллар... Мин сабыр иттем, Түзеп тордым һаман.* Һ.Такташ. *Аз гына, бик аз гына түзәргә, сабыр итәргә кирәк.* И.Салахов

**САБЫРЛАНУ** *ф.* Сабыр кешегә әйләнү; күңел тынычлану. *Салкын сулар эчеп кенә Йөрәгем сабырлана.* Җыр. *Ул моңарчы без белгән Имәли түгел иде инде. Җитдиләнде, сабырланды, хәрәкәтләре дә, теле дә шомара төшкән кебек булды.* М.Әмир. *Ләкин ул соңгы елларда сабырланды кебек, тәүге ашкыну юк, гүя дала буйлап чапкан-чапкан да, теләгән кешесен табып, тынычланып калган иде.* М.Хәбибуллин // Сабыр кыяфәткә керү. *Сәгатьләр буе суга карап утырсаң да сабырланасың.* Н.Гыйматдинова

**Сабырлана бару** Торган саен ныграк сабырлану. *Рәкыйп исә аның саен сабырлана барды, читкә карап тыныч кына көтеп торды ---.* А.Гыйләҗев

**Сабырлана төшү** Элеккегә караганда тагын бераз сабырлану. *– Анысы шулай, – диде Нәбиулла, бераз сабырлана төшеп.* А.Гыйләҗев. *Моның шулай булачагына инанган Мөхәмматҗан, сабырлана төшеп, чит ил музыкасы агылган кибет янындагы эскәмиягә таба атлады.* А.Әхмәтгалиева

**Сабырланып калу** Нindидер вакыйгадан соң сабырлану. *Күк җиһаны бәбидән арынганнан соң сабырланып калган акыллы хатынга охшый иде.* Н.Гыйматдинова

**Сабырланып китү** Соңгы вакытта сабырлану; сизелерлек сабырлану. *Атилла хан почмакта сәке күрде, барып утырды, кымыз сорап алды, агач касәне бармак очларына утыртып,*

*күтәреп эчеп куйды һәм шуннан кинәт кенә сабырланып китте.* М.Хәбибуллин

**САБЫРЛЫ** *с. к.* **Сабыр 1.** (*1, 2 мәгъ.*). *Әдәпле бул – халык сөяр, гыйффәтле бул – Аллаһы Тәгалә сөяр, сабырлы бул – үкенмәссең, тәхәммелле бул – картаймассың, тәхсилең артдыкча – кечелегең, белегең артдыкча – сабырың артсын!* Г.Тукай. *Кыскасы, татар хәзер ничек, элек тә шундый ук сабырлы, башка милләтләргә һәм диннәргә карата итагатьле, хәзергечә әйтсәк, толерант булган.* И.Хуҗин

**САБЫРЛЫК** *и.* 1) Сабыр булу сыйфаты. *Ни генә булмасын, күпне күргән, күпкә түзгән, сабырлыкның чын бәһасен белгән авыл баласы шул ул.* Г.Галиева

2) Сабыр кешегә хас сыйфатлар, тотнаклык, түземлек. *Акъәби, күңеленә ни генә килсә дә, сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча, тыныч кына ята бирде.* Ә.Еники. *Ике сәгать буе көтәргә ничек сабырлыгы җиткән диген.* Л.Шафикова

◊ **Сабырлыгы төкәнү** *к.* **сабыр савыты тулу**. *Шәмсениса абыстай ярты сәгать көтте, бер сәгать – көндәше юк. Сабырлыгы төкәнеп, тагын түбән өйгә төште.* Г.Ахунов

**САБЫРСЫЗ** *с.* Сабырлыгы булмаган, сабырлык күрсәтмәгән. *Бу – сабырсыз хайван иде, пошкырып, дулап китәргә теләде.* Г.Ибраһимов. *Сабырсыз шул хәзер хатыннар да, тиз арада гына ирне, бөгәрләп, олтан астына тыгуны кулайрак күрәләр.* Р.Зәйдулла

2) Сабырсызлыкны чагылдыра торган (караш, мөгамәлә һ.б.ш. тур.). *Күзләре рәхәт йомыла башлаганда гына, Ләйлә, Моратовның сабырсыз күз карашын тоеп, дерт итеп тагын уянып китә.* А.Гыйләҗев

**САБЫРСЫЗЛАНУ** *ф.* Түземсезләнү, сабырсыз кылану, сабырлыкны югалту. *Яңа көн туган саен, әнә шул сөенечкә якынлашкан кебек сабырсызланасың.* И.Салахов. *– Шуннан, шуннан? – дип сабырсызланалар шәкертләр.* Г.Ахунов. *Бу юлы мин алай ук сабырсызланмыйм үзе.* Г.Галиева

**Сабырсызлана бару** Торган саен ныграк сабырсызлану. *Дилбәр минутлар үткән саен сабырсызлана барды.* К.Тимбикова

**Сабырсызлана башлау** Сабырсызланырга тотыну. *Тик бу ябылу бик озакка сузылгач кына, сабырсызлана башладым.* Г.Бәширов

**Сабырсызлана төшү** Бераз сабырсызлану. *– Резидә дә ә-ә-ә итә, – дидем мин, сабырсызлана төшеп.* Ф.Шәфигуллин

**Сабырсызланып алу** Кыска бер вакытка сабырлыкны югалту

**Сабырсызланып китү** Соңгы вакытта сабырсызлану

**САБЫРСЫЗЛЫК** *и.* Сабырсыз булу; түземсезлек. *Мин моны сабырсызлык белән көтә идем.* Г.Ибраһимов. *Эзсез уй, сабырсызлык, тәкатьсезлек адәм баласын котырган эт хәленә җиткерә.* С.Поварисов

**САБЫШУ** *ф. юн. килеш форм.* 1) Исемнәрдән соң: шул халәт тәэсирендә бирелү; салышу. *Аннан аерылгач, ул кайгыга сабышты.* Н.Фәттах. *Әмма эчтән әрни, борчыла, өзгәләнә, бәгъзе берләре чиргә сабыша хәтта.* С.Поварисов. *Фаҗига, эчүгә сабышу шунда башлана.* М.Хәбибуллин

2) Сыйфатлардан һәм *-ган, -мыш* формаларыннан соң: шулай кылану, юри эшләү; салышу. *Ләкин ул бу хакта, ичмасам, бер тапкыр да бер сүз дә әйтмәде, күрсә дә, карчыкны күрмәмешкә сабышты.* М.Хәбибуллин. *Әллә бармаскамы, баш тартыргамы, чирлегә сабышыргамы дип, кат-кат үлчәп, исәпләп карады [Әскәр].* А.Гыйләҗев. *Авыруга сабышкан булып, [Тукай] аларны кабул итми.* Р.Зәйдулла

**Сабышып китү** Соңгы вакытта яки кинәт сабышу. *Гыйшкымнан авыруга сабышып китмәсәм ярар иде.* Ф.Әмирхан

**Сабышып тору** Гел, һәрвакыт сабышу. *Хәер, җүләр булмаса, Сәлим хан бу хакта белергә тиеш иде кебек, ә ул гел белмәмешкә сабышып тора.* М.Хәбибуллин

**САВА́ННА** *и. исп. геогр.* Тропик поястагы сирәк-мирәк кенә куаклар һәм ялгыз агачлар үсә торган дала. *Башта җирдә сәяхәт итәрбез. Тайганы да, саванналарны да күрербез.* А.Тимергалин. *Корылык чорында үләннәр кояш, күп кенә агачлар яфракларын коя, һәм саванналар сары төскә керә.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Жирафлар Африка саванналарында яши.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр

**САВАП** *и. гар. дини* **1.** Нинди дә булса игелекле эш-гамәлләр өчен Аллаһ тарафыннан киләчәк әҗер. *Йөргән аякларыңа җиңеллек, үзеңә күп-күп саваплар иңдерсен бер Аллам.* Г.Галиева. *Мин, ичмасам, авылның ярлы-ябагаен туендырам, алдагы гомеремә савап эшлим.* Ф.Дәүләтбаев

**2.** *с. мәгъ.* Саваплы (*1 мәгъ.*). *Үзем дә бик яхшы беләм хаҗга бару савап эш икәнен.* Ш.Мөхәммәдев

**САВАПЛЫ** *с. дини* 1) Савап казандыра торган (эш, гамәл һ.б.ш. тур.). *Ул баланы укытып, кеше итә алсам, Аллаһым каршында бер саваплы эшем булыры, дип уйлыйм.* Г.Галиева. *Саваплы юлга чыккансыз, карендәш!* А.Хәлим. *Анысы, зур түткәй, мин әйтәм, ирләр муенына муенчак салу бөтен кызларның, тол хатыннарның иң беренче хыялы инде, аннан да саваплы эш юк инде, мин әйтәм.* Г.Мөхәммәтшин

2) Нинди дә булса игелек кылып савап алуга ирешүче (кеше тур.). *– Бәхетле кешеләр, – дип уйланды Җәгъфәр, – нindидер казакъ бае саваплы булсын өчен түгел, үз бәхетләре өчен, үзләренең хәләл акчаларына укырга баралар.* А.Расих

**САВУ** I *ф.* 1) Имчәкне бер кысып, бер бушатып тарта-тарта, сөтне сыгып агызып чыгару. *Күреп алды, дөресрәге, күзенә чагылды: нindидер ишегалдында гун хатыны бия сава.* М.Хәбибуллин. *Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте, Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйтте, тирләп бер йокласам, иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты.* Ә.Еники

2) Имчәк саугандагы кебегрәк хәрәкәтләр ясап, үзеңә таба тарта-тарта чыгарып, җыеп тору (җеп, эчәк кебек нәрсәне). *[Кармагына эре балык эләккән балыкчы үзенең иптәшенә] кармак сабын сузды: – Тот, төшеп савып*

*алам.* Казан утлары. *Әгәр дә без татар тел гыйлеменең җеп очын эзли китсәк, җепне сава-сава, Каюм Насыйрига барып чыгачакбыз.* Х.Сарьян. *Ибрай Зәкуанов сарык суйган, аны лапас өрлегенә бәйләгән тияккә асып туныган, күгелҗем миләүшә төсендәге эчәкләрен озынча тагаракка савып төшергән ---.* Ә.Гаффар

3) Кан тамырларыннан чыгып, организмның берәр өлешендә җыелу (кан тур.). *Зиннәтнең күзен сугып чыгара язды [фашист]. Күз төбенә шунда ук кан савып шешеп чыкты.* Ш.Маннур. *Әти миңа күзлек өстеннән сәерсенеп карый. Кан сауган күзләре бөтенләй кечерәеп калган.* Р.Зәйдулла. *Баш миенә кан саву*

4) *күч. сөйл.* Берәр кешене яки урынны җиңел табыш чыганагы итеп файдалану, аннан табыш-файда алып тору. *[Галләм хаҗи – Сәүбәнгә:] Бераз савып чыгып булмасмы дип килгәнсеңдер.* Ф.Хөсни. *[Мәликә – иренә:] Ул кәнтәе синең тирәдә чытлана икән әле. Кесәңне саварга тели торгандыр.* А.Шамов. *Берни дә бирмичә, безне тагы күпме саумакчы булалар икән?* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Авыр хисләр тудыру, бертуктаусыз газаплау, әрнетү. *Ә... йөрәгемне нидер сава, өзлексез авырттырып сава.* Ә.Еники

**Сава башлау** Саварга тотыну; саву эшенә керешү. *Гөлчирәсе, мәктәптән чыгу белән, фермада сыер сава башлады, ә Гыйззәтҗанны үзең беләсең...* Г.Мөхәммәтшин. *Җаныем да әллә кая үрелмәде, колхозда сыер сава башлады.* И.Салахов

**Савып алу** Хайванның җиленендәге сөтне тулысынча савып бетерү. *Савып алгач, бия сөтен гөбедә күпме пешекләүнең дә әһәмияте бар, диләр.* Ә.Еники. – *Тәгәнәем, түгәнәем,* – *дип, йомшак сүзләр әйтеп, сөтен савып алды да анысын да казанга салып кайнатты.* Г.Ахунов

**Савып тору** Хәзерге моментта яки һәрвакыт, даимән саву. *Аңардан чак кына уңдарак башына ак яулык ураган, өстенә әдрәс камзул кигән бичә, чүгәләп, муенына озын корык салган ап-ак бияне савып тора.* Ә.Еники

**САВУ** II *и.* Саву I (*1, 2 мәгъ.*) эше; савым. *Колхозның --- фермасында менә атна ун-көн инде механикалаштырылган савуга күчәбез дип мәш киләләр.* М.Хәсәнов. *Савымчылар инде бу «күпер» аша ике тапкыр савуга чыккандыр.* Р.Батулла. *Тамак ялгагач, тагын сыер савуны дәвам иттек.* Безнең гәҗит

**САВУЧЫ** *и. к.* **савымчы**. *Алар җәйләүгә барып җиткәндә, кичке савым беткән, савылган сөт озатылган, савучыларның өлкәннәре авылларга таралышкан, Зәйтүнәнең әнкәсе дә кайтып киткән иде.* А.Гыйләҗев

**САВЫГУ** *ф.* **1.** 1) Кабат сау хәлгә кайту, авырудан туктау, сәламәтләнү. *[Карчык:] Каны чыкмаган. Бозык каны эчтә җыелып калган. Шул чыкмыйча савыкмас.* Н.Фәттах. – *[Санаторийдан] Савыгып кайт, Дилә!* – *Савыгырга иде дә, Идрис, ничек булыр.* А.Гыйләҗев. *Галимә кайгыдан бетерешкән иде, балага җылымны күргәч савыкты.* Н.Гыйматдинова

2) Ял итеп, спорт белән шөгыльләнеп һ.б.ш. элеккедән дә ныграк сәламәтләнү. *Курорттан савыгып кайту*

**2.** *и. мәгъ. Чөнки бу – чир галәмәте түгел, савыгу билгесе иде.* А.Тимергалин. *Савыгу чоры*

**Савыга бару** Торган саен савыгу

**Савыга башлау** Савыгырга тотыну. *Кадрия гүя Фәргатькә көч өсти, ул әкияттәгечә ел савыгасын ай савыга башлый.* Ватаным Татарстан

**Савыга төшү** Тагын бераз савыгу, сәламәтләнү. *Тик саташу һәм истән язулардан бөтенләй арынып савыга төшкәндә, ул инде таш калада, врачлар карамагында дәвалана иде.* Г.Бәширов

**Савыгып бетү** Тәмам савыгу, чирләрдән арыну. *Авылга кайтканнан соң, Мәүлетдин дүрт елдан артыбрак киткән вакыт эчендә тулысынча савыгып бетә алмады.* З.Зәйнуллин. *Врачлар авылга тәмам савыгып бетәргә җибәрәләр.* Р.Ишморатова

**Савыгып җиту** Тәмам савыгу. *Кыш җитте, шәкертебез һаман савыгып җитә алмый.* Ш.Камал. *Карале, сылукай, син әлегә савыгып җитмәгән.* Ш.Фәрхетдин. *Савыгып җиту өчен, авылыгызга кайтаралар үзеңне.* Р.Ишморатова

**Савыгып килү** Инде савыга башлау

**Савыгып киту** Соңгы вакытта савыгу

**САВЫКТЫРУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **савыгу** // Сау хәлгә кайтару. *Анасы да, атасы да бөтен көчләрен куеп, уларын тизрәк савыктырырга тырыштылар.* Ә.Фәйзи. *Ямьсезләрне чибәрли, азгыннарны йөгәнли, симезне ябыктыра, тилене савыктыра, исерекне айныта, хәерчене баета!..* М.Кәбиров

2) *күч. кит.* Яхшырту, нормальләштерү (мөнәсәбәт, хәл, шартларны). *Дәүләтара мөнәсәбәтләрне савыктыру*

**2.** *и. мәгъ.* Сәламәтләндерү. *Бу, үз чиратында, шешләрне иртә стадиядә ачыклау мөмкинлеге, элек үлемгә дучар булган авыруларны савыктыру мөмкинлеге бирде.* Кызыл таң

**Савыктыра төшү** Тагын бераз савыктыру

**Савыктырып бетерү** Тәмам сәламәт хәлгә китерү

**САВЫЛ** *и. диал.* Чагыл; яшь каенлык. *Савыл арасы түгел, авыл арасы.* Мәкаль

**САВЫЛУ** *ф. йөкл. юн.* 1) *к.* **саву**

2) *күч.* Әкрен генә, аз-азлап кая да булса керү яки кайдандыр чыгу. *[Пароходтан] Савылып халык чыгарга тотынды.* А.Гыйләҗев. *Вакыт, бармаклар арасыннан савылган ком бөртекләредәй, кешегә уч иткән сыман, туктаусыз ага да ага бирә.* Ф.Әһлиуллина. *Төтен савылып торбага керә* // Булган урыннан шома гына шуып төшү. *Хәйрүш савылып һавага күтәрелгәнен тойды. Аттан аерылды...* Р.Зәйдулла

**Савылып килү** Күптәннән савылу. *Ял йортына дип алынган гарнитурның теге җитәкче квартирына кереп утыруын каян белгән диген дә, ун мең сыер урынына күп еллар буе егерме мең сыер савылып килүен кемнән ишеткән диген!..* Ф.Баттал

**САВЫМ** I *и.* **1.** 1) Бер савуда яки билгеле бер вакыт эчендә алына торган сөтнең күләме. *Чөгендер күп бирелгәндә, сыерларның савымнары да арта.* А.Расих. *Саттар Хәбирәсе, кем әйтмешли, ике аягына берьюлы аксый*

*башлады. Кулыннан эш төште. Савымы бермә-бер кимеде.* М.Хәсәнов. *Аталык савым. Савым графиклары*

2) Саву эше. *Чыннан да, берничә мәртәбә, балыкка баргач, сыер савучы кызларның төшке савымнан соң күлдә су коенганнарын камыш арасыннан качып кына карап торганы бар иде аның!..* А.Гыйләҗев. *Сыерларны кичке савымга әзерләү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Саудыра, сөт бирә торган (сыер, бия һ.б.ш. хайван тур.). *Абышка үзе исән, мал-туарлы вакытында – ике савым дөя, бәрәннәре белән бергә унбишләп куй сарыгы бар вакытта – яхшы ата иде.* Ч.Айтматов. *Болар белән бергә куй, сыер көтүләре, колынлы савым бияләре кузгалды.* Г.Ибраһимов

2) Саву (*1 мәгъ.*) өчен хезмәт итә торган, саугыч (**1.**). *Шулвакыт савым аппаратын карауч механик – шулай ук безнең яшьтәш – Нурмөхәммәт килеп чыкты ---.* М.Мәһдиев

◊ **Савым сыер** *гади ирон.* Шәхси мәнфәгатьләр өчен һәрвакыт һәм бернидән дә тартынмыйча файдаланган кеше көче яки матди байлык чыганагы. *Оятсыз рәвештә аны файдаландылар ич! Уенчык итеп... Юк, савым сыеры урынына...* Р.Зәйдулла. *Торфтыр, тирестер, ашламадыр кайтаруга тоткан бөтен чыгымнарны чигергәч тә, елына ике мең тәңкә бирә торган савым сыер икән аның бакчакайгынасы!* А.Тимергалин

**САВЫМ** II *и.* 1) *махс.* Җеп үлчәү берәмлеге: тегәрҗептә – бер бөртеккә, тырмага озаткан җептә – өч бөртеккә, киләпле җептә дүрт бөртеккә тигез

2) *этн.* Туйга алып барыла торган күчтәнәч, азык-төлек

3) *диал.* Коръән ашына алып барыла торган күчтәнәч

**САВЫМЛА́У** *ф. махс.* Савымнар (II) белән санау, ничә савым икәнен билгеләү (*җептән*)

**Савымлап чыгу** Барысын да савымлау

**САВЫМЧЫ** *и.* Сыер савучы һәм аларны карау эшендә эшләүче. *Ә-ә, бу синме әле? Сәҗидә кызымы? Теге безнең савымчы кызларны елаткан Мәрьямме?* Н.Гыйматдинова. *«Юлия әле кайчакта сеңелләре Гөлсинә белән Рәсимәне дә ияртеп килә, барысы да савымчы булачаклар», – ди [Әфтәхетдин абый].* Р.Йосыпова

**САВЫР** I *и.* **1.** 1) Атта: сыртның янбаш тирәсе, билдән алып койрыкка кадәр булган өлеш; бүлтәк. *Алтын да ияр, штуф мендәр Акбүз атның йөри саурында.* Җыр. *Бүре Бадул сары бия янына килеп, аның савырын сыпырды.* Г.Ахунов. *Савыр ите* // Кешедә: янбашның арткы өлеше, йомшак җир, арт сан. *[Хатын], француз үкчәләрен тротуар ташларына бәрә-бәрә, тулы савырларын калтыратып, чайкала-чайкала китеп барды.* К.Тинчурин. *Остабикә дә, кондырлы кодача кебек, савырын сала да утыра, сала да утыра.* Г.Ахунов

2) Атның шул урыныдагы тиресеннән эшләнгән күн

**2.** *с. мәгъ.* Шул күннән тегелгән, эшләнгән; саурый. *Гүләп-гүләп йөрешле, Гелән савыр итекле, Господалар муенлы, Муены тулы җелекле, Яшел камка янчыклы, Тальянский яулыклы (күркә).* Табышмак. *Савыр читек*

**САВЫР** II *и. бот.* Туя агачы

**САВЫРЛА́У** *ф.* Савыр күне куеп эшләү (аяк киемен). *Улының аягындагы читеге кай таба! Савырлап каеган өр-яңа читек, ә?!* Ә.Фәйзи

**Савырлап кую** Тиз арада савырлау

**САВЫРЛЫ** *с.* Савыр күне куеп эшләнгән (читек һ.б.ш. тур.). *Савырлы читек урынына тупас итек киячәген уйлап, [Вахитның] йөрәге калтыранып китте.* М.Гафури. *Әптелбәрнең дә Апушныкы кебек савырлы читеге була...* Ә.Фәйзи. *Аягында савырлы кәҗүл читек.* М.Галәү

**САВЫТ** *и.* 1) Түгелә-чәчелә торган һ.б.ш. нәрсәләрне салып саклау-йөртү сыешлыгы. *Уртак савыттан кымыз эчкәч, ике арада үзеннән-үзе туганлык, якынлык барлыкка килде.* Н.Фәттах. *Соңгы вакытта аны гел чүп савытлары тирәсендә күрәләр иде, ул шуннан калдык икмәк кисәкләре, бәрәңге кабыклары алып кергән икән.* Р.Зәйдулла. *Кара савыты. Шикәр савыты. Су савыты. Көл савыты. Кершән савыты*

2) Аш сала торган тәлинкәдән тирәнрәк табак. *Мәрьямбикә өстәлдән ашны, савытларны җыйнап алды.* Г.Ибраһимов. *[Ят эт] Акбүзнең оясы янына килеп, савыттагы инде бозланып өлгергән ашны кимерде.* Г.Гобәй. *Биктимер савытларга буы чыгып торган шурба салды.* Р.Зәйдулла

3) Берәр әйберне салып саклый торган тартма, тышча, футляр һ.б.ш. *Казыктагы чөйгә ул иң элек иплән кенә җәясен, аннары ук тулы авыр ук савытын элде.* Н.Фәттах

4) *сөйл.* Кечкенә балаларны тустыру чүлмәге

5) *тар.* Кораллы бәрелешләр вакытында арка-күкрәкне җәрәхәтләнүдән саклау өчен, тоташ металлдан эшләнгән хәрби кием. *Ак савытның якасы бар – җиңе юк, чын яхшының ачуы бар – үче юк.* Мәкаль. *Шаһ Тимердән бер батыр – Уң кул бие Ир Каплан, Кигәне көмеш ак савыт, Көн ярыктай балк итеп, Тугыз батман, тугыз теш Туң чукмарын кулга элеп, Ат сикертеп уртага, Мәйдан тотып туктады.* Дастан. *Моны белгәннән соң, ике мәргән шайланып яуга чыктылар. Савыт киеп атышырга чыктылар.* Риваять. *Батыр егет килә ат өстендә, Аты уйный авызын тартканда. Булат савыт кигән, сөңге тоткан, Ташны яра уклар атканда.* Җыр

6) *биол.* Саранчалар семьялыгына кергән бөҗәкләрнең үзенчәлекле бүлентеләре белән туфрак аралашуыннан хасил булып, кышын күкәйләр өемен саклау өчен хезмәт итә торган махсус каты тышча; *русчасы:* **кубышка**

◊ **Савыты тулмаган** Тинтәк, юләр

**САВЫТЛЫ** *с.* 1) Савытка салынган; савыты булган. *Хәлвәфрүш, башына савытлы хәлвә күтәреп, патша сарае янынан уза.* К.Насыйри. *Җамали, кулындагы савытлы суын идәнгә куеп, смирно басты.* М.Гали. *Теге калай савытлы чәйне үзең карап тотарсың инде!* Ватаным Татарстан

2) Савыт (*2 мәгъ.*) кигән. *Савытлы яугир*

**САВЫТ-САБА** *җый. и.* Азык-төлек салып саклау яки йөртү өчен хуҗалык кирәк-яраклары. *Арбаларга бикәнең киез өйләре, кием-салымнары, савыт-сабалары, бөтен бер кышка җитәрлек*

*азык-төлеге – барлык байлыгы, барлык кирәк-ярагы төялгән иде.* Н.Фәттах. *Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлыюклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде.* Ә.Еники

◊ **Савыт-саба шалтырау** Гаиләдә вак-төяк тавыш булгалау. *Гаиләбез ишәйгән саен, өйдә бераз савыт-сабалар шалтырый башлады.* В.Хәйдәрова

**САВЫТ-САЙМАН** *җый. и. иск.* Ук, җәя, калкан, көбә кулмәк, шишәк кебек кораллар һәм саклану киемнәренең һәммәсе; корал-ярак. *Шалтыр-шолтыр чыңлап савыт-сайман, Өстебездә сөңге җайнады.* Ш.Бабич

**САГ** I *с. иск.* Уң, уң яктагы. *Ики йүз беӊ эр ашар саг янындан, ики йүз беӊ эр ашар сул янындан, ики йүз беӊ эр ашар һәм уӊындан, – һәм ардындан ики йүз беӊ ашар имди.* Кол Гали

**САГ** II *и. гар.* Мөселманнарда авырлык үлчәү берәмлеге. *Мәрҗани хәзрәтләре үзенең матди ярдәмчеләре булган кайбер байларга, шөбһә һәм ихтилафтан чыгар өчен, бер саг хөрмә яки илебездә бер саг хөрмә күпме торса, шулкадәр акчаны садака итеп бирергә кирәклеген аңлаткан.* Дин вә мәгыйшәт

**СА́Г** *и. махс.* 1) Аткы (таяклы, шакмаклы уенда – бәрә торган таяк, тәпәч; кузналы уенда – эрерәк, авыррак кузна). *Малайлар, ике партиягә бүленеп, өй каршындагы тигезлектә шакмак уйныйлар. Бер як сага тондырганда, икенче як, күзләрен тасырайтып, уен кагыйдәләрен бозмыйлармы каһәрләр дип карап тора.* И.Гази

2) Чүпрәктән тегелгән яки сыерның ябагасыннан әвәләп-укмаштырып ясалган кечкенә туп

**СА́ГА** *и. сканд. әд.* Борынгы Скандинавия һәм Борынгы Ирландия халыклары әдәбиятында алыплар һәм илаһлар турында язылган чәчмә эпик хикәят. *Тәрҗемә ителгән сагалар. Ялган сагалар*

**САГАЙ** *и.* Хакас халкының бер этник төркеме һәм шул төркемнең вәкиле. *Хакас теленең сагай диалекты*

**САГАЙДАК** *и. к.* **садак**

**САГАЙТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сагаю**. *Тычканны аяк тавышлары сагайтты ахрысы, яраткан эшеннән туктады.* Р.Зәйдулла. *Борһан колакларын сагайтты.* М.Мәһдиев

**Сагайта төшү** Тагын бераз сагайту. *Егетнең кайгылы тавышы Динәне сагайта төште.* Н.Гыйматдинова

**САГАЛАК** *и. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан Төньяк диңгездә үрчи торган эре балык; ялангач балык; *русчасы:* **голец**

**САГАЛА́У** *ф.* Яшеренеп яки сиздермичә генә кемнең дә булса килеп чыкканын яки нәрсәнең дә булса барлыкка килгәнен көтү. *Күпме генә яхшы күренмә син, Эт сагалый сине капкада.* Х.Туфан. *Сине, тәгин углан, җир өстендә адым саен үлем сагалый.* Н.Фәттах // Тотып алу, һөҗүм итү, берәр нәрсә эшләтү һ.б.ш. максатлардан кемне яки нәрсәнедер күзәтү. *Малай алда йөри, мин артыннан, Үзем йөрим, үзем сагалыйм: Минем атны суга-нитә калса, Тотып яңакларга чамалыйм...* Һ.Такташ. *Язын да, көзен дә сагалады, тездән кар ерып, кыш буе да урман эчен айкап йөрде, барыбер үтерә алмады...* Н.Гыйматдинова

**Сагалап йөрү** Гел яки озак вакыт сагалау. *Ярты ел акча җыйдым, бер ел сагалап йөрдем дә эләктердем мин моны [моторны].* М.Әмир. *Мәликә, аның [тавыкның] кайда йомырка салганын белергә дип, берничә көн сагалап йөрде.* А.Шамов

**Сагалап тору** Һәрвакыт яки озак вакыт сагалау. *Адым саен аларны үлем сагалап торды.* Н.Фәттах. *Икенче көнне карда янында Җамал Исхакны сагалап торып, эттән алып эткә салды...* А.Гыйләҗев

**Сагалый килү** Күптәннән һәм дәвамлы рәвештә сагалау. *Аларны гел әллә нинди бәлаләр, куркынычлар сагалый килә: уй-сурәтләр кискенләшә, олы кешеләр, кулларын җәеп, балаларына ярдәмгә ташланалар.* Ф.Бәйрәмова

**САГАЛДЫРЫК** *и.* 1) Йөгәннең ияк асты каешы

2) *к.* **сакалдырык**

**САГАЛМА** *и. диал.* Кыргый алмагач

**САГАЮ** I *ф.* 1) Игътибарны арттыру, саклык-сизгерлек тойгысын көчәйтү. *Яшь угланның сүзләре аларны сөенергә дә, сагаерга да мәҗбүр итте.* Н.Фәттах. *Тәүге сөю газапларын татып, Яшь йөрәкләр кайчак сагая.* Р.Чурагулов. *Күрдем сине кичә төшемдә: Җыерчыклар маңгай-битеңдә. Син көләсең миңа елмаеп, Уяндым мин куркып, сагаеп.* И.Хөснетдинов

2) Сак булуны белдерә башлау (тавыш, чырай һ.б. тур.). *[Фәтхи] уйларын бер урынга җыярга теләгән сыман, тагын җитдиләнде, тавышы да сагайды.* Г.Бәширов. *Аннары, тирә-ягындагы мохитне аңлагач, аның көлүе сагая, иреннәренә ирония чаткылары куна.* Ф.Әһлиуллина

**Сагаеп калу** Кинәт сагаю; берәр сәбәптән сагаю. *Шул вакыйга уңае белән газетачылардан сагаеп калды ул [Ренат]!* А.Гыйләҗев. *Маһирә үзенә тигән агач кашыкны әйләндергәләп карый башлауга, чулпылар чыңлавын ишетеп, сагаеп калды.* Г.Галиева

**Сагая калу** *к.* **сагаеп калу**. *Таңчулпаны аны китапханә ишеге янында каршы алды һәм, ир-канатының караңгы йөзен күреп, сагая калды.* М.Хәбибуллин. *Нурия аның шыпыртлап әйткән сүзеннән сагая калды.* Г.Ахунов

**Сагая төшү** Тагын бераз сагаю. *Тимери, сагая төшеп, алга атлады.* Г.Бәширов. *Мин сагая төштем. Әллә инде минем тарафтан уйламаган җирдән берәр тупаслык яки этлек эшләнеп ташланганмы?* В.Монасыйпов

**САГАЮ** II *и.* Саклык, сизгерлек, дикъкать. *Ашыгып, елмаеп, шулай да эчке бер сагаю белән ул тәхет каршысына килеп тезләнде.* Н.Фәттах. *Сагаю да бар иде ул күз тирәнлегендә, тик сукыр мәхәббәт аны күрмәде, абайламады...* А.Гыйләҗев. *Ниндидер бер сынауны, әллә сагаюны, яшерен күзәтүче шикелле, безне рәсмирәк булырга, дистанция сакларга мәҗбүр итә иде.* Ә.Еники. *Хәзер инде аның тавышындагы корылык һәм сагаю беткән иде.* Г.Әпсәләмов

**САГАЮЛЫ** *с.* Сак, сизгер; саклыкны белдерә торган. *Шуннан соң ул тирә-ягына сагаюлы күз карашы ташлап алды да, Сафага таба иелә төшебрәк, ярым пышылдап сүзен дәвам итте: – Өйгә кайтыр өчен сиңа,*

*якташкаем, бернинди паспорт та кирәкми.* М.Галәү. *Тукай урынында кала бирде, ләкин аның карашы да, тавышы да сагаюлы иде: – Мин әле бернәрсә дә төшенмәдем, – диде.* Р.Батулла

**САГЛАМ** *с. кит.* 1) Сәламәт, сау, исән, таза. *Саглам егет*

2) Куәтле, көчле, ныклы. *Камал паша хәрәкәте бу – төрек милләтчелегенең бүгенге иң саглам һәм иң самими хәрәкәте.* Ф.Әмирхан. *Саглам халык*

3) Таза, нык, чыдам. *Саглам карагайлар шартлап ярыла [суыктан].* Д.Фәтхи

4) *күч.* Ышанычлы, дөрес. *Моны халык үзенең саглам зәвыгы белән сизми кала алмады.* Ф.Әмирхан. *Саглам фикерле*

**СА́ГО** *и. малай* Саго агачлары үзәгеннән алынган крахмалдан яки, шуңа охшатып, бәрәңге һәм кукуруз крахмалыннан ясала торган ярма. *Сагоны башкача да бүрттерергә мөмкин.* Ю.Әхмәтҗанов. *Саго боткасы. Саго кушылган бәлеш*

**СА́ГО АГАЧЛАРЫ** *и. бот.* Пальмалар семьялыгыннан дымлы үзәннәрдә, елга буйларында үсеп, кәүсә үзәкләреннән саго ярмасы ясар өчен крахмал алына торган агач үсемлекләр төркеме

**САГЫЗ** *и.* 1) Ылыслы үсемлекләрдә исле, агып чыккач куера торган, ябышкак, үзле сыекча матдә; чәер. *Кабаклары шешенке күзләре ачылмый гына Әскәрнең, такырлана башлаган киң маңгае өстәл лампасыннан төшкән саран яктылыкта җансыз балавыздай ялтырый, сәмих сагызы төсле куе төкереге ап-ак батист мендәргә тамган.* А.Гыйләҗев. *--- кояш нурында җылынган сары нарат бүрәнәләрдән җанга ятышлы сагыз исе килә, йорт эче бик тын иде.* Г.Ахунов

2) Кайбер агач бөреләрендә, үләннәрдә була торган ябышкак, үзле сыекча, куе сүл. *Агач бөресенең сагызы кулга ябышу. Билчән сагызы. Сөтлегән сагызы*

3) Ылыслы үсемлекләрдән агып чыккан үзле сыекча матдәне яки каен тузын кайнатып ясалган һәм чәйнәү өчен кулланыла торган, җылыда йомшару үзлегенә ия масса. *Зөләйхадан ярдәм һаман килгәләп тора икән, шуның өстенә җиңгәчәй, каен тузыннан сагыз кайнатып, хатын-кыз арасында сатткалый икән.* Ә.Еники. *Шул арада берсе «чарт» итеп сагызын чартлата ---.* М.Мәһдиев. – *Үзебезгә күрә тырышабыз, – диде игезәк кызларын ике беләгенә алган Сәгыйдә җиңги, лачлоч сагыз чәйнәп.* А.Хәлим // Эластик нигезгә төрле тәмләткечләр кушып ясалган һәм чәйнәү өчен кулланыла торган кулинария әйбере. *Кая, элек лифтёрларның телефоннары язып эленгән була торган иде. Язылган булган, тик саннар өстенә сагызмы, әллә нәрсә чәпәп куйганнар.* М.Кәбиров. *Кавын исле сагыз. Сагыздан куык өрү*

4) Колак куышлыгында барлыкка килә торган көрәнсу сары, майлы куе матдә. *Ишетүнең начарлануы колак тишегендә ябышучан матдә – колак сагызы җыелудан булырга мөмкин.* Биология. *Сагыз җыелып, колак томаланса, колакка тоз яки аш содасы эремәсе тамызалар.* Ватаным Татарстан. *Колакка сагыз утыру*

5) *күч.* Әрсезләнеп яки ялагайланып, яннан китмичә бәйләнеп торучы. *Нинди сагыз бу Мингаян түти, кунакка тын алырга да ирек бирми: бер алдына, биш артына төшә.* С.Рафиков. *Юлда очраган һәр Валя хатының була башласа... Бер сагыз ул.* Л.Шафикова

◊ **Сагыз булу** *к.* **нарат сагызы (чәере) булу**. *[Мәсәгутов] Туган якларын, татарларның ничек яшәүләрен, --- даладагы бакчаларда карбыз саклап яткан марҗа кызларының аңа сагыз булуларын бик кызык итеп кичләрен безгә сөйли торган иде.* Ә.Еники. *Шахтёр егет шундый итеп ялынды, бәйләнде, тәмам сагыз булды.* М.Мәһдиев. *Пелагея Николаевнасы да сагыз булды бит шул чакта.* Р.Ишморатова

**САГЫ́З АГАЧЫ** *и. бот.* Сумахчалар семьялыгыннан, кәүсәсеннән хуш исле чәер – мастика, җимешләреннән ашарга яраклы май сыгып алына, яфракларыннан сары буяу ясала торган мәңгеяшел куак яки кечкенә агач; *русчасы:* **мастиковое дерево**

**САГЫЗАК** *и.* 1) *зоол.* Шөпшә, азман. *Сагызак, күпме безелдәсә дә, бал җыймас.* Мәкаль. *Сагызак угы. Сагызак чагу*

2) *к.* **сагыз** (*5 мәгъ.*). *[Солдат сорау бирә-бирә төпченүче иптәшенә:] Бәйләнчек, сагызак!* Казан утлары

**САГЫЗЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сагызлау**. *Юкка чыккан малайлар мәдрәсәсе урынына Мөхәммәтҗан хаҗи сагызланып торган наратлардан 1907 елда буе 42, иңе 21 аршинлы мәктәп салып бирә.* В.Имамов // Үзенә сагыз (*1, 2 мәгъ.*) буялу, сылану яки сеңү. *Скрипканың да, сызгычның да кыллары бик нык сагызланды.* Ә.Фәйзи. *Агач бөреләре хуш ис аңкытып, сагызланып яшәрделәр.* А.Расих. *Нарат кискәндә пычкы сагызлану. Чүп утаганда кул сагызланып бетү*

2) Сагызга (*1, 2 мәгъ.*) әверелү яки сагыз сыман хәлгә килү. *Үләннең сүле һавада сагызлану*

3) Сагыз (*3 мәгъ.*) утыру. *Майлы чәчләре арасыннан тырпаеп торган, сагызланып каткан колагына пышылдап кына дәштем.* А.Зәки

4) *күч.* Әрсезләнеп яки ялагайланып, яннан китмичә һаман бәйләнеп тору. *Хөрмәт күрсәт – яраклашма, сагызланма.* Н.Арсланов. *Рәйхана кабат кыстау-сагызлануга урын калдырмаслык итеп әйтте.* Р.Ишморатова

**Сагызлана бару** Торган саен ныграк сагызлану. *Карт тирәкләрне сырган бөреләр дә көннән-көн бүртә, сагызлана бара: тиздән, бәлки, нәни яфракларның очлары да күренә башлар.* Ә.Еники

**Сагызлана башлау** Сагызланырга тотыну. *Сүс өмәсендә тана колак Хөснулла Хәбире бик сагызлана башлагач, Банат тегеңә киле сабы белән кундырган.* И.Гази

**Сагызлана бирү** Һаман сагызлану, сагызланудан туктамау. – *Син кем соң? – Борис нидер хәтерләргә теләп, маңгаен җыерды, булдыра алмады. – Ничек инде «кем?» – дип сагызлана бирде Әфган ветераны.* М.Шаһимәрдәнов

**Сагызлана төшү** Тагын да ныграк сагызлану; бераз сагызлану

**Сагызланып бетү** Тәмам сагызлану

**Сагызланып йөрү** Гел бәйләнеп, куштанлану

**Сагызланып тору** Сагызланган хәлдә булу

**САГЫЗЛА́У** *ф.* Сагыз (*1, 2 мәгъ.*) сылау, йоктыру; нәрсәнең дә булса өстенә сагыз сылау. *Сызгычны [скрипкәгә сызып] сызгырта торган хәйләне мин генә беләм дип йөри идем, аны син дә белеп алгансың икән! Син аны сагызлагансыңдыр әле?* Ә.Фәйзи

**Сагызлап алу** Тиз арада сагызлау

**Сагызлап кую** Озакка сузмыйча сагызлау

**Сагызлап чыгу** Барысын да яки тулысынча сагызлау

**Сагызлый төшү** Тагын бераз сагызлау

**САГЫЗЛЫ** *с.* 1) Сагызы (*1, 2 мәгъ.*) булган, сагыз бирә торган. *Язлар җитә башласа, Кадриянең йөрәге яшь чаклардагы төсле җирси, ул, үзләреннән ерак та түгел урнашкан паркка барып, сагызлы тупыл бөреләре, каенга кунган сыерчыклар белән гәпләшеп йөри.* А.Гыйләҗев. *Аның сары сагызлы бөреләре коелган көннәрдә, бакчада парфюмерия фабрикасы күчеп килгән сыман була, бала вакытта без ул бөреләрдән ислемәй ясап карый идек...* М.Мәһдиев

2) Сагызланган, сагызга буялган. *Бигрәк тә калын, сагызлы язгы йонны үтәр-үтмәс кайчылар белән кырку бик авырга килә иде, әле кайбер хайванкайларның йоны «купмаган» булып, ала-тилә итеп тә җибәрә идек...* Татарстан яшьләре. *Сагызлы кулны керосин белән юу*

3) *күч.* Сыланып ябыша торган. *Юл пычрак. Тарантас тәгәрмәчләренә уралган сагызлы балчыкның авырлыгы арта бара.* К.Нәҗми. *Авыз тирәсе майланган, колак тишекләренә шалкан чәчәрлек булган, ямаулы ыштан кигән сагызлы чәчле малаеның кулына кабартма кисәге тотып урамга чыкканына тап булган әти кеше болай гына, бәхете ташыганнан гына, әлеге сагызлы башка берне биреп ала.* М.Мәһдиев

**САГЫЗЛЫ́ ЧӘЧӘК** *и. бот.* Чыпчык җилеме, дегет чәчәге; *русчасы:* **смолка**

**САГЫМ** *и. к.* **мираж** (*1 мәгъ.*). *Бу коры, җилсез, тын эсселектән даланың төрле ягында, көмеш тулкыннары белән уйнаган диңгез кебек, сагым ялтырый.* Г.Ибраһимов

**САГЫНДЫРГЫЧ** *с.* Искә төшеп сагындыра торган. *Бу тавышлар, бу моң, бу яңгыраш, бу аһәң – болар барысы да кечкенә генә бер кешенең кечкенә генә бер дөньясындагы күңел кылларын тирбәтеп, аны студент елларына алып киттеләр дә сагындыргыч хатирәләргә илтеп ташладылар.* Ж.Юныс. *Һәр усакта калган үткән көннән Сагындыргыч матур истәлек.* М.Җәлил

**САГЫНДЫРУ** *ф.* 1) Сагыну хисләре уяту. *Нигә сагындыра ул авыл, һич башыма сыймый.* Р.Зәйдулла. *Җәйләр җитсә, бигрәк сагындыра Яшел хәтфә болын-тугайлар.* М.Гобәйдуллин

2) *з.-сыз* Сагыну биләп алу, эч пошу. *Бергә чакта беленми ул, Күк күгәрчен, сандугачым, Аерылгач сагындыра.* Җыр. *Зәңгәр күлләр کояшларда Күзләрне чагылдыра. Иң беренче сине күргән Чакларны сагындыра.* В.Казыйханов. *Чит илләрдә шунысы кыен: Сагындыра кич-иртә.* Ш.Хисмәтов

**САГЫНМАКЛЫК** *и.* **сагынмалык**. *Хатлар язган Корбан аңарга, Сагынмаклык итеп карарга.* Ш.Маннур. *Тальян гармунын өстәлгә куйды да әйтте: «Менә, улым, көмеш телле яшел гармуным сагынмаклык булып кала».* Сөембикә

**САГЫНМАЛЫК** *и.* Сагынганда карар өчен истәлек әйбере. *Чирәм буйлап чишмә суына Өч кат бара идем көненә; Суга йөргән яшел көянтәмне Сагынмалык бирдем сеңлемә.* Җыр. *Син аңа ярарлык язу, шулай ук ярарлык сагынмалык җибәрергә боерсаң иде.* Һ.Атласи

**САГЫНУ** I *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса искә төшереп күрәсе килү, юксыну, аның янәшәсендә булырга теләү. *Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык.* Ә.Еники. *Нургалинең үзе уйнап җырлаганын шулкадәр сагынганнар күрәсең, аңа кушылырга берсе дә җөрьәт итмәде.* Г.Галиева

2) Тансыклау, күңел теләү. *Аның бик кызык бер гадәте бар: ул чиктән тыш арпа коймагын ярата, хәзер шуны сагына.* М.Мәһдиев

**Сагына башлау** Сагынырга тотыну. *Ноябрьгә керүгә, кышны сагына башлыйбыз.* Ватаным Татарстан

**Сагына төшү** Тагын да ныграк сагыну

**Сагынып бетү** Бик нык сагыну. *[Җизни:] – Үзең соң, үзең? Аена ничә керәсең?.. Әнә оныкларың сагынып беткән монда, – ди.* Г.Бәширов. *Сине озак көттек бит Һәм сагынып беттек бик.* Мөҗәһит

**Сагынып кую** Кинәт, сирәк яки әледән-әле сагыну хисе кичерү. *Ул Ырымбурга, туганнары янына кайтып киткән Көмеш түтәйне үзәкләре өзелеп сагынып куя.* Г.Ахунов. *«Юк, болар арасында йөрсәң, авырмас җирдән авырырсың», – дидем дә үзебезнең Аккош күле урманнарын сагынып куйдым.* Г.Әпсәләмов

**Сагынып тору** Даимән, һәрвакыт яки хәзерге моментта сагыну

**САГЫНУ** II *и.* Сагыну хисе, сагыныч. *Сагынуларны, сәламнәрне Җилгә бүләк итимме, Әллә фәкать йөрәгемдә, Йөрәк белән бергә шулай Җиргә-гүргә илтимме?* Х.Туфан. *Нургалинең безгә дигән хаты бик әйбәт язылган, ике сүзнең берендә Хафиз белән сине сагынуы турында яза.* Г.Галиева. *Вакыты җиткәч, ул үзенең мәхәббәте белән очраша, сагыш, сагыну, ялгызлык дигән дәрьяга чума.* Ф.Әһлиуллина

**САГЫНУЛЫ** *с.* 1) Сагыну катнаш (хисләр тур.). *[Ана белән кызы арасында] каты әрнүле шелтәләр белән бергә сагынулы мәхәббәт үпкәләре түгелде.* Г.Ибраһимов. *Сагынулы куаныч*

2) Сагындыра, сагынып көтелә торган (вакыт, чор, вакыйга һ.б. тур.). *Шундый сагынулы минутларның берсендә Гәрәй [истәлек актарып укый башлады].* А.Гыйләҗев. *Сагынулы көннәр. Сагынулы бәйрәм*

3) Сагынуны белдерә, күрсәтә, сиздерә торган. *Мин юаныч табам күңелемә Сагынулы җылы хатыңнан.* М.Хөсәен. *Җиде яшемдә вакытта минем бөтен гомерем буена тирән бер авыр, сагынулы эз калдырган батрак улы Мөхәммәтҗан-Мокамай исемле бер иптәшем бар иде.* Һ.Такташ. *Сагынулы җыр. Сагынулы сәлам*

**САГЫНЫЧ** *и. сир.* Сагыну хисе. *Күрәсең, ул чаклар хәзер инде Сагыныч булып җырга кушыла.* Ш.Маннур

**САГЫНЫЧЛЫ** *с. к.* **сагынулы**. *Кизләү тавының кеше күзеннән яшерен аралыгына атлаганда, Фәнис әнә шул сагынычлы хатирәләрне күңелендә яңартты.* Ш.Алпар. *Барчагызга сагынычлы сәламемне җибәреп, сәламәтлегемне белдерәм.* А.Алиш. *Сагынычлы ул тәрәзә.* А.Хәлим

**САГЫНЫШУ** *ф. урт. юн.* Берберсен сагыну. *Әллә кочаклашалар инде? Ай-һай, сагынышканнар!* М.Шаһимәрдәнов // Булган һәркем сагыну. *Җирдә калган өмет-хыялларын сагынышып җырлыйлар [дулкыннар].* Н.Гыйматдинова. *Казлар китә, ә без – якын дуслар – Сагынышып килдек күрешергә.* М.Ногман

**САГЫШ** *и.* 1) *иск.* Уй, фикер; уйлау, фикер йөртү, тәфәккер. *Ишан сагышын сагышлап, Ишан рухына багышлап, Ашап-эчеп, күңел хушлап, Гулять иттем Урайкинда.* Г.Кандалый

2) Кемне яки нәрсәне дә булса нык юксыну, сагыну аркасында туган борчылу катыш моңаю, эч пошу кебек ямансу хис. *Кылганнарның сары йөзләрендә Сары сагыш, зәңгәр зар гына.* Х.Туфан. *«Менә нишләтә язмыш!» – дип уйлады ул, тирән бер сагыш һәм әрнү белән.* Н.Фәттах. *Ике-өч сәгатькә генә булса да, сагышларымнан аерылып торам.* Г.Галиева

**САГЫШЛАНУ** I *ф.* 1) Сагышка, төшенкелеккә бирелү, моңаю. *Үзенеке буласын алдан ук белеп торганга ахрысы, беркайчан да ул Елдырым бәкнең Алтын-Бөртек кызын уйлап сагышланмады.* Н.Фәттах. *Шундый шат күңелле хатын иде ул, бер генә минутка да сагышланырга, моңаерга ирек бирмәде.* А.Гыйләҗев

2) Сагышны белдерә, күрсәтә, сиздерә башлау, сагышлы (*2 мәгъ.*) төскә, кыяфәткә керү. *Аның күзләре сагышланды, тавышы да кинәт йомшарып, бөтенләй моңсуланып китте.* А.Шамов. *Айсылу, Мәрьямнең сагышланып түбән караган ябык йөзенә күз салып, аның кәҗәсен сатарга уйлавының сәбәбен белергә тырышты.* Г.Бәширов

**Сагышлана башлау** Сагышланырга тотыну. *Газинур урман кисәргә киткәч, гөлләр ничектер ямансулый, сагышлана башлады.* Г.Әпсәләмов

**Сагышланып алу** Беразга сагышлану. *Моңланып, сагышланып та ала ул, яшь тә сыгып куя, көлеп тә җибәрә.* Г.Гыйльманов. *Туган мәктәбем тарихы битләренә бу саннар теркәлер көннәр җиткәндә, берникадәр уйланып та, сагышланып та алдым.* Өмет

**Сагышланып бетү** Тәмам сагышлану

**Сагышланып йөрү** Гел сагышлы булу. *Язмышын эзләп йөргән кеше генә шулай онытылып, сагышланып йөри ала.* Г.Гыйльманов

**Сагышланып китү** Соңгы вакытта яки моментта сагышлану. *Күзләре сагышланып китте җаныкаемның.* Ф.Баттал

**Сагышланып кую** Кинәт кенә сагышка бирелү. *Челтер-челтер итеп чишмә ага, Сагышланып куя күңелләр.* Х.Касыйм

**Сагышланып тору** Гел, әледәнәле яки хәзерге моментта сагышлану. *Авылга кайтырмын инде, дип сагышланып торганда, Хатирә каршында Хәмәтдин пәйда була инде, – очрамаган булса канә!..* М.Шаһимәрдәнов

**САГЫШЛАНУ** II *и.* Сагыш, төшенкелек, боеклык. *Карт ниндидер тирән сагышлану белән уфырып тын алды.* А.Хәлим

**САГЫШЛА́У** *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса уйлау, кайгырту. *Ләкин... Ләкин... Бәндә сагышлый – Ходай багышлый, мин авылга керә алмадым.* М.Мәһдиев

2) Сагыш хисенә бирелү, моңлану. *Шамил кияү шулай ышандыргач, Ананың да күңеле тынычлап, Кайгы шәлен салды йөрәгеннән, Йөрмәс булды юкка сагышлап.* Ф.Яхин. *Күзләрендә бәгырьләрне Үксетерлек моң тулы, Милләт язмышын сагышлап Сискәндергән шом тулы.* Ш.Галиев

**Сагышлап йөрү** Гел сагышлау, сагынып уйлау

**Сагышлап тору** Сагыш хисенә бирелгән хәлдә булу

**САГЫШЛЫ** *с.* **1.** 1) Сагышы, гаме булган, сагыш хисләре кичерүче. *Бәлки, ул җырны сагышлы әсир үзе уйлап чыгарган булгандыр.* Н.Дәүли. *Димәк, сагышлы кеше – әйбәт кеше.* Г.Гыйльманов

2) Сагыш катнаш, сагыш тулы (хисләр, уйлар тур.). *Мин кайнар мәхәббәт хакында язмыйм шул. Мин күбрәк сагышлы, моңсу хис-тойгылар белән язам...* Г.Гыйльманов. *Канифә татлы да, сагышлы да уйларга чумды.* Н.Көбәш

3) Сагыш эчендә үтә торган (вакыт, гомер һ.б. тур.). *Сезнең алдагы гомерегез сагышлы булачак, диләр.* Г.Гыйльманов. *Син югалдың офык томанында, Гел сагышлы көннәр җиттеләр.* Р.Вәлиев

4) Сагышны белдерә, сиздерә, күрсәтә торган (караш, тавыш һ.б. тур.). *Диңгез-күл буйлары аның күңелендә мәңге яз булып, туктаусыз шаулаган дулкыннар булып, очар кошларның сагышлы авазлары булып сеңеп калган иде.* Н.Фәттах. *– Юк, анысы ук булмас, булмас, – диде күршем сагышлы тавыш белән.* И.Салахов. *Атның күзләре моңсу, сагышлы, ямансу иде.* С.Поварисов

5) Сагыш барлыкка китерә торган. *Бикбулат карт бу сагышлы йортта шуның белән эшен бетереп чыгып та китте.* Г.Бәширов. *Өметсезлек тулы сагышлы хат иде бу...* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Сагыш белән. *Таңчулпанның туган ягында да тыңлаганы бар сандугачлар моңын, тик болай сагышлы сайрамыйлар кебек иде.* М.Хәбибуллин. *Алай ук моңлы-зарлы булуын теләмәсәм дә, гел сагышлы чыга минем әсәрләр...* Г.Гыйльманов

**САГЫШЛЫК** *и. сир. к.* **сагыш**. *Ничек кенә булмасын, шундый коточкыч вакыйганы исенә төшергәннән соң, бу минутта аның күзләрендә һичшиксез булырга тиеш булган моңсулыкның, сагышлыкның һәм --- үкенүнең әсәре дә юк иде.* А.Шамов

**САГЫШЧАН** *с. сир.* 1) Сагышка бирелүчән

2) Сагышны һәм сагынганлыкны белдерә, күрсәтә торган (кыяфәт һ.б. тур.). *[Марат] үзенә бикләнүчән, тирән кичерүчән һәм бераз сагышчан кыяфәттә.* Н.Исәнбәт

**САДА** *и. гар. иск. кит.* 1) Аваз, тавыш. *Бу моңлы иптәшемнең күз карашы, Тагын да әллә нинди ят садасы Дигән төсле була: «Мондин кучик без, Канатлан син дә, сахрага очыйк без!»* Г.Тукай. *Венгрның садасы Хәтфәгә бер таныш сада кеби ишетелде.* М.Акъегетзадә

2) Шәкертләр үзләре чыгарган яки, бүтән автор тарафыннан язылып, шәкертләр телендә йөргән җыр, декламация һ.б.ш. *[Шәкертләр] яңа программалар сорап, садалар, марсельезалар әйтеп, мәдрәсә ташлап чыкканнар.* Н.Исәнбәт. *Шәкертләр садасы. Сада җырлау*

**САДАК** *и.* 1) Җәя һәм уклар савыты. *Миңа бер садак тулы ук бирсәң, шул җиткән.* Н.Фәттах. *Биктимер аның тунын салырга булышты, җәясен, садагын бер читкә алып куйды.* Р.Зәйдулла

2) Укчының җәя һәм аның савытыннан, уклар һәм ук савытыннан торган корал комплекты. *[Идегәй] Җирдә яткан садагын Иелеп алып бер киде.* Дастан

3) *диал.* Укның бер төре. *Садактан йөгерек ук булмас, атсаң, тимер кап чыдамас.* Мәкаль

**САДАКА** *и. гар.* Мохтаҗ, ярлы кешеләргә ярдәм йөзеннән бирелә торган акча яки әйбер. *Габбас мулла, садака-мазар бирергә кирәк булса дип, бер янчык көмеш акча әзерләде.* Г.Ахунов. *– Садака эләктерер өчен түгел инде, – диде ул, көлеп. – Чиркәү хорын тыңлый идем...* Ә.Еники. *Фитыр садакасы. Юл садакасы. Гүр садакасы. Зәкят садакасы* // Нинди дә булса җәмәгать эшенә акчалата яки әйберләтә ярдәм, иганә. *Мәчет салдырырга садака җыю*

**САДАКА́И ҖАРИЯ** *и. гар. дини* Кеше үзе вафат булгач та аңа савабы килеп торган садака. *Гыйлем өйрәнеп кое казыса, елга казып су йөртсә, савабы киселмәс, боларны садакаи җария диерләр.* К.Насыйри

**САДАКАТЬ** *и. гар. иск.* Тугрылык, тугры сүзлелек, эчкерсезлек. *Гыйффәт, садакать даирәсендә булмаган мәхәббәт сәфаһәт, начарлык буладыр.* М.Гафури

**САДАКАТЬЛЕ** *с. иск.* Тугрылыклы, тугры, ышанычлы

**САДАКАЧЫ** *и.* Садака алучы, садака җыючы. *Ял көненә атап алар кайткан иделәр, теге садакачы яшь хатыннар килеп, район газетасындагы үзләре хакындагы мәкаләне аларга суздылар.* Ф.Яхин

**САДӘ** *с. фар. кит.* 1) Бик гади, катлаулы булмаган. --- *елмая-елмая яткан диңгез ягасында чүмәшкән килеш, үзенең садә генә ал күлмәге һәм башындагы күк яулыгы белән, ул [Газизә] түгәрәк кенә ләтыйфь бер гөл чәчәгенә охшый иде.* Ш.Камал. *Бактерияләрдә, аннары амёба кебек садә организмнарда ул [сиземләү сәләте] тагы да катлаулырак һәм зуррак үсешкә ирешкән.* А.Тимергалин

2) Эчкерсез, самими, саф күңелле. *Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә – бик гади, бик садә кешеләр.* Ә.Еники. *Ни бу? Садә бер дуслыкмы? Аннан да югарырак булган серле, сихерле, аңлаешсыз бер төшенчәме?* С.Поварисов

**САДӘЛӘНҮ** *ф. кит.* Гадиләшү. *Картлар кушуы буенча, ул мулла булып калган һәм, әүвәлге белән чагыштырганда, соң дәрәҗәдә садәләнгән вазифаларын үтәп яшәгән.* А.Тимергалин

**Садәләнә бару** Торган саен садәләнү

**Садәләнә башлау** Садәләнүгә табан үзгәрү

**Садәләнә төшү** Тагын бераз садәләнү

**Садәләнеп китү** Соңгы вакытта садәләнү

**САДӘЛӘШҮ** *ф. кит. к.* **садәләнү**. *Дача халкы да бөтенләй бер гаилә шикелле булып беткәннәр, иялләшкәннәр, мөгамәләләре садәләшкән.* Ф.Әмирхан

**Садәләшә бару** *к.* **садәләнә бару**

**Садәләшә башлау** *к.* **садәләнә башлау**

**Садәләшә төшү** *к.* **садәләнә төшү**

**Садәләшеп китү** *к.* **садәләнеп китү**

**САДӘЛЕК** *и. кит.* 1) Гадилек. *[Тукай] тормышында садәлекне һәр нәрсәдән алда күрә торган кеше иде.* Ф.Әмирхан

2) Эчкерсезлек, саф күңеллелек, табигыйлек. *Газизәнең сөйкемле һәм җитди чыраенда, садәлек катыш чын кыланышында, кешенең күңелен үзенә тарту белән бергә, аны бер төрле хөрмәт иттерә торган бер хасият бар иде.* Ш.Камал. *Ләкин аның бөтен кыяфәтеннән бик саф күңелле кешеләргә генә хас садәлек, самимилек һәм, шуларның чагылышыдай, үзенә бер мөлаемлык бөркелеп тора.* Ә.Еники. *Кичәге сабырлык, садәлек аша зәһәр тамчылар биешә, табалмыйм тынгы, табалмыйм!* Н.Гыйматдинова

**САДИЗМ** *и. фр. [маркиз де Сад исеменнән] к.* **садистлык**. *Ерткычлык һәм садизм аның [фашистның] иң яраткан эшләреннән иде.* Ш.Маннур. *Аларда кешеләрне нинди юллар белән үтерергә --- – бөтенесе-бөтенесе җентекләп өйрәтелә, имансызлык, кансызлык, мәрхәмәтсезлек, садизм дәресләре бирелә, шуларның технологиясе детальләп күрсәтелә.* Ватаным Татарстан

**САДИСТ** *и. фр. кит.* Башкаларны җәзалаудан рәхәт, ләззәт табучы кеше. *Баш түбәсендәге чәчләрне бетергәч, әкренләп, муен белән чигә тирәсенә күчте теге «садист».* Аманулла

**САДИСТЛЫК** *и. кит.* 1) Башка бер кешене җәзалау яки кимсетүдән канәгатьлек алу, азгынлык

2) Садист булу; садист кешегә хас сыйфатлар

**САДЫЙК** *с. гар. иск.* Тугры; дөрес сүзле, эчкерсез. *Башка төрек илләренең истикъляльче агымнары да шулай ук алган кыйблага, шулай ук берлегебезгә садыйк булып калачакларына ышанып, милли кортылыш тартышыбызның яңа адымын атларга хәзер торабыз.* Г.Исхакый

**САЕГАЮ** *ф. диал. к.* **саегу**. *Генофондыбыз саегая дип зарланып утыру көлке бит, билләһи...* Р.Зәйдулла

**Саегая бару** *к.* **саега бару**. *Бу – инешнең авылга таба саегая барып сазлану һәм сызлану ишарәте.* А.Хәлим

**САЕГУ** *ф.* 1) Сай I (*1, 2 мәгъ.*) булып калу, сайга әйләнү. *Бу төбәктәге башка күлләр дә саекты, күбесе кибү алдында тора.* А.Гыйләҗев. *Авылда болыннар корыган, күлләр саеккан, бәрәңгеләрне коңгыз ашаган.* Н.Гыйматдинова. *Инеш саегу. Чишмә саегу. Тирән кое саегу*

2) *күч.* Бик кимү, аз калу, бетүгә якынлашу (азык-төлек, эш, акча һ.б.ш. тур.). *Бераз эшләр саеккач, көн саен кичләрен Бибиәсма аркау җеплек эрләде.* Д.Каюмова. *Запас саегу* // Нәрсәнең дә булса эчендәге әйбере нык кимү, бетә язу (баз, бура, азык-төлек саклый торган сыешлык һ.б. тур.). *Шәвәлине эчереп, Кесә төбе саекты.* М.Саттаров. *Нәсихка да, балаларга да киемнәр сатып ала башлагач, Галяның акча яньчеге бик тиз саекты.* Ш.Алпар

3) *күч.* Зәгыйфьләнү, начарлану, кимү, бетү ягына бару (акыл, рухи сыйфат һ.б.ш. тур.). *Күрәсең, нәкъ шушы мизгелдә актарылып чыгасы шатлык вакыт узу белән саеккан булгандыр инде.* Р.Зәйдулла. – *Хәтерең саега башлаган, карчык, – дип, Талип абзый көлеп куя.* Н.Гыйматдинова. *Тел байлыгы саегу*

**Саега бару** Торган саен ныграк саегу. – *Нигә алай, Исхак? Елга елдан-ел саега бара, ә ташулар көчәя бара, дип сөйлиләр.* А.Гыйләҗев. – *Бик кәектең әле, энекәш, әллә утыз икегә кыстырырга саегып барамы эшләр? – дип, аны бер көнне Шәйхи карт дәшеп туктатты.* М.Мәһдиев. *Идел койган диңгез саега бара, Кешеләрнең хәтере шикелле.* Р.Вәлиев

**Саега башлау** Саегырга тотыну. *Үзүзен генә яратучы һәм мәхәббәтен кашыклап өләшүче эгоист ирләр күбәеп киткән җәмгыятьтә әхлак чишмәләре саега башлый.* Р.Низами

**Саега төшү** Тагын да саегу; бераз саегу. *Бер-берсеннән бик зур вакыт аралыгында торулары сәбәпле (13 мең ел), кешелек дөньясы аларны оныта барган, һәр «йокыга талу» дәверендә, кешелек дөньясының акылы шактый саега төшеп, кешеләр ирешелгән бик күп казанышларын югалта, оныта торган булганнар.* С.Шәмси

**Саегып бару** *к.* **саега бару**. – *Кызганыч, бүген авылыбызда да милли рух саегып бара, – дип ачынып сөйләде Туфан абый.* Безнең гәҗит

**Саегып бетү** Тәмам саегу. *Елгалар саегып беткән.* Кызыл таң. *Диңгез урынына, авылга кайтып, саегып беткән елга суында коенып килдем.* Ватаным Татарстан

**Саегып калу** Кинәт саеккан хәлгә килү. *Су буенда уйнашып йөргән балачага өчен дә кызыклы иде тып-тыныч диңгезнең шул рәвешле кинәт кенә саегып калуы.* Р.Мөхәммәдиев. --- *ул елны кояш апрель башларында ук кыздырырга тотынды, бөтен нәфрәтен туплап кыздырды ул: бөреләр шартлап ачылу белән саргаеп катты, үләннәр калкынып чыга алмады, елгалар кибеп саегып калды, җиргә яланаяк басарлык булмады.* М.Кәбиров

**Саегып китү** Соңгы вакытта саегу. *Чишмәбаш мөгаллиме (исемен оныттым инде, бу елларны хәтерем саегып китте, рәхмәт төшкере) сер итеп кенә әйтеп җибәргән, ни дигән, Шәпкүлгә шушы арада тикшерүчеләр килә, --- дигән.* Г.Мөхәммәтшин

**САЕН** *бәйл.* 1) Исемнәрдән һәм *-ган* формасыннан соң: кабатлануны белдерә. *Һәм барган саен, каганга, аның бичәләренә, яраткан кол кызларынакырнакларына бүләкләр алып барды.* Н.Фәттах. *Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем ашарга утырган саен кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә иде...* Ә.Еники

2) *-ган* формасыннан соң: бер эшхәлнең дәвам итүе яки көчәюе нәтиҗәсендә икенче эш-хәлнең көчәюен, үсүен, интенсивлашуын белдерә. *Югарыга күтәрелгән саен кечерәеп күренгән аксыл саргылт кояш яктысында, бер болытсыз чалт аяз күк йөзе астында иксез-чиксез дала җәелеп ятты.* Н.Фәттах. *Җыен көне якынайган саен, Газзәбануның күңелендәге кара шом да үскәннән-үсә барды.* Г.Галиева

3) *-ган* формасыннан соң: кабатлап әйтелгән фигыльләр арасында килеп, дәвамлылык төсмере бирә. *Юк, белмисез, яшьләр, Белмисез сез: Торган саен торасы килә...* Х.Туфан. *Бигрәк тә үзеннән соң талантлы яшьләрнең килүе аның кәефен боза, көнләшү чире азган саен аза, һәм ул, җае чыкса, теле белән булса да сине ваксыта иде.* Н.Гыйматдинова

**САЕСКАН** *и. зоол.* Каргалар семьялыгыннан, аклы-каралы каурыйлы, озын койрыклы, шыгырдаган өзек-өзек тавыш чыгара торган кош. *Саескан сайрау белән сандугач булмас.* Мәкаль. *Сине сагына бары күрән җәллад, Кара козгын, ала саескан.* Х.Туфан

**САЕСКА́Н ҖИЛӘГЕ** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан шәмәхә, сирәк кенә ак чәчәкле үрмәләп үсә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **паслён сладко-горький**

**САЖИН** *и. рус* 1) Метрик система кертелгәнчегә кадәр кулланылган өч аршынга тигез озынлык үлчәү берәмлеге (2,13 м). *Тыкрык һәм читән буйларында кар эскертләре, тау-тау өелеп, өй һәм сарайлар белән тигезләнә, ун-унбиш сажиннан читтә бернәрсә күренми, туктаусыз буран улый иде.* Ш.Камал. *Кеше-кара күренмәгәч, эреэре атлап, ике-өч сажин ераклыктагы зирек куакларына таба китте.* А.Гыйләҗев. *Ике йөз сажиннар ары кәҗә сукмагы бар.* Г.Ахунов

2) Шул озынлыкка тигез махсус үлчәү коралы; өчпочмак. *Җир бүлгәндә, печән өләшкәндә, шобага белән сажин таяклары да аның кулында.* Г.Бәширов. *Әле үзе үлчәп йөргән сажин таягы бүген дә исән, кичә барышында, аларның тормыш юлын сәхнәләштергәндә, әлеге хезмәт коралы да кулланылды.* Ватаным Татарстан. *Сажин тотып үлчәп йөрү*

3) Нәрсәнең дә булса шул үлчәүгә салынган күләме (гадәттә саннар белән күрсәтелә). *Ике квадрат сажин утын. Унбиш сажин җир*

**САЖИНЛА́У** *ф.* Сажин белән үлчәү, сажинга салу. *Урмаган игенне сажинлап бүлегез, урганын көлтәләп.* З.Зәйнуллин

**Сажинлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр сажинлау

**САЖИНЛЫ** *с.* Ничәдер сажин (*1 мәгъ.*) озынлыгындагы. *Сажинлы таяк. Унбиш сажинлы эскерт*

**САҖА** *и. кыт. зоол.* Болдырык кошлар семьялыгыннан далаларда һәм чүлләрдә яши торган, өч бармагы да бергә тоташып табан асты хасил иткән аяклары тырнакларына кадәр каурыйлар белән капланган күчмә кош; *русчасы:* **копытка**

**САЗ** I *и.* **1.** 1) Урыны-урыны белән өстенә су чыгып торган, дым яратучан

үсемлекләр белән капланган баткак җир. *Торна сазын тикшерергә мелиораторлар килә дигәннәр иде, мөгаен, шулардыр.* А.Гыйләҗев. *[Нәзирә:] Кайдан бу тавыш? Саздан, мүк чыгара торган җирдән.* Ю.Әминов

2) Артык сулану-юешләнү нәтиҗәсендә җебеп баткакка әйләнгән җир, аяк асты. *Пычрак саз ерып йөгерәләр иде алар абыйлары артыннан.* Р.Мөхәммәдиев. *Урамдагы ләшпердек сазның өсте юка боз белән капланган.* Г.Сабитов

3) *күч.* Торгынлыкка төшкән яки артта калган, яңалыкка каршы булган даирә, тормыш һ.б.ш. *Сәлимов бөтен гомере буенча хатыннарны, вак, түбән мещан сазыннан чыга алмый, дип хурлаучы кешеләрдән иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ. к.* **сазлы**. *Кар астыннан яңа чыгып килә торган саз балчыкны балтырдан ерып, кышын түгелгән чүп өемнәрен актарабыз.* Ш.Маннур. *Саз вакытында да ул [Сиваш култыгы] бик үк юаш түгел.* Г.Бәширов

**САЗ** II *и. фар. шигъ.* 1) Төрки халыкларда кыллы музыка уен коралларының гомуми атамасы (думбра, дутар, гуд, танбур һ.б.ш.). *Дагстанлы карт һаман саз чалып утыра...* Ш.Камал. *Аның көрән статуэткасын (саз уйнап утырган гарәп хатыны иде шикелле) кайсыдыр дустыбызның туган көненә алып бардык.* Г.Мөхәммәтшин. *Тамгачы бәкнең акшарлаган кебек чырае, куе шәмәхәгә тартым чәчләре, яшькелт күзләре, саз уйнаучыныкы кебек нәфис бармаклары хыялый бер җан иясенекен хәтерләтә иде...* А.Тимергалин

2) Шундый уен коралларының аерым бер төре

3) *күч.* Шагыйрь, музыкант кебек иҗат кешеләренең илһамы, иҗат дәрте, бик иҗат итәргә теләү халәте. *И мөкаддәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?* Г.Тукай

**САЗА** *с. сир. к.* **сазаган**. *[Байның] дәүләтен тартып алдылар, сусыз кабып йотардай сылу кызы саза калды: бай егетләрендә кызлар кайгысы калмаган иде.* Казан утлары

**САЗАГАН** *с.* Өйләнмичә яки кияүгә чыкмыйча бик озак торган. *Сазаган карт кызның үпкәләве бар иде.* М.Хәбибуллин. *Комбинатта бер иш халык төйнәлгән, шомалар, каһәр! Сазаган чуртаннар сыман... Берсе бажа, берсе кода, әкәмәт...* А.Гыйләҗев. *Канатлы булсын кызың, сазаган кыз булып өйдә утырып калмасын.* Г.Ахунов

**САЗАМЫК** *с. к.* **сазаган**. *Берәр кызың сазамык булып утырып калса, нишләр идең?!* З.Садыйков

**САЗАН** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан эре тәңкәле төче су балыгы. *Биш-алты тачка йомычка балык, сельдь, унбиш-егермеләп биреш, эре генә өч сазан чыкты.* Ш.Камал. *Әле тәлинкәле үлчәүгә балыкны салып, бабай белән келәттә үлчәп тә чыктылар. Унике килолы сазан икән.* А.Хәмзин

**САЗАНАК** *и. бот.* Арчаннар семьялыгыннан исертә торган исле, мәңгеяшел саз куагы; *русчасы:* **багульник**. *Үги ана, сазанак, бака яфрагы үләннәреннән ясалган төнәтмә эчегез.* Ватаным Татарстан. *Сазанак – --- мәңгеяшел вак куак, кайчакта биеклеге 1 м га җитә, әмма күбесенчә 20–30 см дан артмый.* Урман аптекасы

**САЗА́У** I *ф.* Өйләнү яки кияүгә чыгу яшеннән узып китү. *Мулла асравы килеп керде. Кияүгә чыкмый сазаган кыз ул. Ат чаклы зур, җен кебек усал.* Г.Гобәй. *Әйе, ярый-ярый, Мәймүнә үк булмаса, кайсы да бата, болай сазап картаю яхшы түгел бит инде, кешедән оят, билләһи!* Ф.Яхин

**Сазап бару** Әкренләп сазау. *Сазап бара торган улларының башлы-күзле булуына ата-ана бик куанды.* Д.Каюмова

**Сазап калу** Сазаган хәлдә булу. *Чыннан да, аның белән бер бүлмәдә көн итүчеләрнең барысы да, яшьлек-үсмерлекләре сугыш елларына туры килгәнлектән, сазап калганнар шул.* Р.Рахман

**САЗА́У** II *с. к.* **сазаган**. *Шакир гөнаһсыз яшүсмер түгел, азмы-күпме дөнья күргән сазау егет инде.* С.Сабиров

**СА́З БИЗГӘГЕ** *и. бот. к.* **сазлавык уты**

**СА́З ҖИЛӘГЕ** *и. бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан сазлыкларда үсә һәм ак чәчәк ата торган үлән үсемлек һәм шуның кызгылт сары хуш исле ашарга яраклы баллы җиләге; мырак; *русчасы:* **морошка**

**СА́З ЙОЛДЫЗЫ** *и. бот.* Бакаяфрагычалар семьялыгыннан үлән саз үсемлеге; су йолдызы; *русчасы:* **болотник**

**СА́З КОНДЫЗЫ** *и. зоол.* Нутрия. *Саз кондызы һәм куян тиреләрен эшкәртергә өйрәнеп, алардан үзе үк бүрекләр текте.* Шәһри Казан. *Саз кондызы, диңгез мәчесе, чәшке туннар да җылылыкны яхшы саклый.* Безнең гәҗит

**САЗЛАВЫ́К УТЫ** *и. бот.* Күрәнчәләр семьялыгыннан дымлы урыннарда үсә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **ситняг, болотница**

**САЗЛАМЫК** *и.* **1.** *к.* **сазлык** (*1 мәгъ.*). *Көз булса да, һавалар җылы торып ахрысы, уң яктагы дачалар арасында бер ашъяулык кадәр генә калган сазламыкта бакалар кычкыра.* А.Гыйләҗев. *Кинәт кызның күңеле кузгалып, бәләкәй чаклары, тегермән буасы янындагы сазламыктан бака балалары алып кайткан чаклары исенә төште.* Г.Ахунов. *Юл да алай батып ятарлык сазламык түгел...* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ. к.* **сазлык 2.** *Сазламык юлдан шәһәргә колхозның кызыл обозы атлады.* А.Алиш. – *Бу урманнар, сазламык җирләргә болгарлар кайдан килеп утырганнар? – диде.* Г.Гобәйдуллин

**САЗЛАМЫКЛАНУ** *ф. к.* **сазлану**. *Күл буе сазламыкланган, әйләнәсен тәбәнәк камыш баскан, ләкин урталыкта су ялтырый иде.* А.Тимергалин

**Сазламыклана бару** Торган саен ныграк сазламыклану

**Сазламыкланып бетү** Тәмам сазламыклану

**Сазламыкланып китү** Соңгы вакытта сазламыклану

**САЗЛАМЫКЛЫ** *с. к.* **сазлы**. *Сазламыклы урман. Сазламыклы юл*

**САЗЛАНУ** *ф.* Сазга (*1, 2 мәгъ.*) әйләнү. *Борма урамнар юлы сазланса да, Адәм йөремәслек булса да... Ударниклар һаман бертуктаусыз, Бертуктаусыз һаман эшлиләр.* Ш.Маннур. *Яр буйларындагы түбәнлекләр сазланган.* Материклар һәм океаннар географиясе

**Сазлана бару** Торган саен сазлану

**Сазланып бетү** Тәмам сазлану

**Сазланып китү** Соңгы вакытта яки билгеле моментта сазлану. *Әнә бездән аста Кырлыганның Мендәрле Кул чишмәсе койган урыныннан киңәеп һәм сазланып киткән агымы, күзге кыйпылчыкларын хәтерләтеп, күзләрне чагылдыра-чагылдыра ялтырап ята...* А.Хәлим

**Сазланып тору** Гел, һәрвакыт сазланган булу. *Ул такыр төбеннән бүген дә тоз чыгып ята, кайбер урыннары сазланып тора.* Ч.Айтматов

**Сазланып яту** Сазланган хәлдә булу. *Мин атны бәрәңге бакчасының сазланып яткан урталыгында мүк кебек күпереп үскән кондырак үләнгә тышаулап җибәргән арада, ишегалды ягында аларның тавышлары тынды.* А.Хәлим

**САЗЛЫ** *с.* Сазланган, сазга әйләнгән. *Алар анда, көтүлек өчен уңайсыз, сазлы, ташлы җирләрдә, дөге игеп, яшелчә үстереп, балык тотып көн күрәләр.* Н.Фәттах. *Лычтыр-лычтыр-лычтыр... Авыр итек сазлы юлны изә дә изә.* К.Тимбикова

**САЗЛЫК** *и.* **1.** 1) Сазлы җир. *Сазлык өсте куе камыш урманы белән капланган.* Н.Фәттах. *Төньяк Америка сазлыкларында чебен тәбесе дигән үсемлек очрый.* А.Тимергалин. *Ул [торна] мүк, мүк җиләге яисә тәбәнәк чыршы белән капланган урман сазлыгында яши.* Кошлар

2) *күч.* Торгынлыкка төшкән яки артта калган, яңалыкка каршы булган даирә, тормыш һ.б.ш. *Ир кеше өчен моның ике куркыныч ягы бар: беренчесе – үзеңне гайбәтче хатын-кызлар сазлыгына төшерү, икенчесе – ялагайлык кәсафәте.* С.Поварисов. *Сәясәт сазлыгына кереп батканнар алар.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Сазланган, сазлыкка әйләнгән; сазлы. *Сазлык җирләр*

**САЗЛЫ́К БЕЛЕМЕ** *и.* Физик географиянең сазлыкларны өйрәнә торган тармагы. *Сазлык белеме нигезләре. Сазлык белеменең теоретик проблемалары*

**САЗЛЫКЛАНУ** *ф.* Сазлыкка әйләнү, сазлану. *Авылга кереп, бер-ике тыкрык үткәч, алар кечкенә инеш агып сазлыкланган урам аша авыл артындагы урманга юл тоттылар.* Д.Каюмова

**Сазлыклана бару** Торган саен ныграк сазлыклану

**Сазлыклана башлау** Сазлыкланырга тотыну; сазлануга таба бару. *Ярыйсы гына киң тоелган юл да тарая, сазлыклана башлады, һәм... мотоцикл да сүнде.* Ф.Баттал

**Сазлыкланып бетү** Тәмам сазлыклану

**Сазлыкланып китү** Соңгы вакытта сазлыклану

**САЗЛЫКЛЫ** *с.* Сазлыгы булган, сазланган. *Бер башы Мөрәле дигән авылга – кара сазлыклы урамнары белән --- әллә ниткән кырыс холыклы, әмма каты куллы морҗачы, мунчала чыгаручылардан торган авылга таба бара.* М.Мәһдиев. *Йортлары авылның кырыенда, Тал Борыны дип йөртелгән сазлыклы җирдә урнашкан.* З.Зәйнуллин

**СА́З ПЕЧӘНЕ** *и. бот. диал.* Күрән

**СА́З ҮЛӘННӘРЕ** *и. бот.* Әкрен агымлы яки тын сулыкларда үсә торган үсемлекләр семьялыгы; *русчасы:* **болотниковые**

**СА́З ЧИЯСЕ** *и. бот. диал.* Нарат җиләге, кызыл көртмәлек

**САЗЧЫ** *и.* Саз (II) уйнаучы, шуның остасы

**СА́З ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Солы чыпчыклары семьялыгыннан йорт чыпчыгына охшаган сайрар кош; *русчасы:* **камышовая (тростниковая) овсянка**. *Әле яңарак кына күкәйдән чыккан, сары томшыклы, чыршы күркәсе кадәрле генә саз чыпчыгыннан алып, корыган агач ботагында: «Килделәр дә киттеләр, килмәгән тик булдылар», – дип, үзе яшәгән чорда дөньяга килеп киткән җан ияләре турында уйланып утыручы, гомеренең инде, мөгаен, өченче йөзен ваклаган карт козгынга кадәр яши Каратамак атавында.* Ф.Шәфигуллин

**СА́З ЯРАНЫ** *и. бот.* Торнабаш, торна үләне

**САИЛ** *и. иск. гар.* Теләнче, хәерче

**САИЛЧЕ** *и. ялг. к.* **саил**. *Сугыш елында, беләсең бит инде, саилчесе дә күренә башлады.* Х.Сарьян. *«Саилчеләргә, сукбайларга монда урын юк, күздән югал!» – диде [сакчы].* А.Расих. *Зур базарлы сәүдә җире саилчеләрне һәрвакыт үзенә тарткан.* Ә.Еники

**САЙ** I *с.* **1.** 1) Тирән түгел (сулыклар, чокырлар, шулай ук савыт-саба, баш һәм аяк киемнәре һ.б. тур.). *Сай күлләрдә каралышып беткән Каңгылдашып йөргән аккошлар.* Х.Туфан. *--- күлмәк изүләрен чишеп, пинжәкләрен, камзулларын җилбәгәй җибәреп, киез эшләпәле, кырпу сай бүрекле картлар төркем-төркем булып урам уртасыннан узалар.* А.Гыйләҗев. *Өстәл уртасындагы зур сай тәлинкәдәге бәрәңге, кишер өстенә ит турап өелгән, читендә суган бөҗралары.* М.Кәбиров

2) Аз яки кимчелекле (акыл, хәтер һ.б.ш. тур.). *Күрәсең, аның уе сай, төпле түгел, акылы такыр, зиһен шөребе буш, хис-тойгысы коры.* С.Поварисов. *Ә бездә грамот сай, дөресен әйткәндә, юк бездә грамот, юк...* А.Тимергалин

3) Тәҗрибәсез, белеме җитәрлек түгел. *Мулла, политикадан сайрак булса да, Курманаев әфәнденең фәлсәфәсен бик тиз аңлады.* И.Гази

4) Эчтәлеге, кыйммәте ягыннан әһәмияте зур булмаган. *Чынлап та, күләмнәре белән бик кечкенәләр, мәгънә ягыннан да сайлар, кыскасы, шома гына язылган вак кына әдәби парчалар.* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тирән булмаган урын (суда). *Тоз баржасы сайга утырган.* И.Гази. *Чәбәк-чәбәк-чәбәк, күрдек алтын чабак. Алтын чабак кайда? Тыпырчына сайда. Аны сайдан алдык, тирән суга салдык.* Р.Харис. *Җиде көнлек юлны болар ун тәүлектә үтәргә мәҗбүр булалар, чөнки «Пионер» сайга утыра.* Р.Батулла

2) *диал.* Тугай, үзәнлек, болын култыгы. *[Хатын-кызларга һәм балачагага урманның җиләкле урыннарын күрсәтеп йөрүче:] Аннан менә теге сайга төшегез. Мин арырак китеп тагын эзлим.* М.Фәйзи

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Сабанны тиешенчә тирәнгә кертмичә (сөрү тур.). *Сай сөрәләр кайбер сабаннар.* М.Җәлил

2) Тиешле дәрәҗәдә түгел, өстәнөстән генә (фикер йөртү тур.). *Синеңчә, сайрак уйлаганда, шулай да бит...* Г.Бәширов

◊ **Сайдан йөзү** *к.* **сай йөзү**. *Ул сайдан йөзә, әкрен кыймылдый.* Ә.Камал.

**Сай йөзү** Берәр өлкәдә бик аз белем белән эшләү яки бик өстән генә фикер йөртү. *Хатын-кызның сай йөзүеннән көлеп, секретарь иңбашларын сикертеп куйды.* Г.Бәширов. *Галимҗан Алмабикәнең фикер кылын тартып карады. Кылы буш түгел болай. Әдәбият, сәнгать ярата. Дөрес, бу өлкәдә әле сай йөзә.* С.Поварисов. **Сай сөрү** *к.* **сай йөзү**. *[Әхәт:] Кеше үзе турында берни дә яшермичә кайда сөйли ала? Я, я! [Идрис:] Юлда сөйли, ерак юлда, вагонда. --- – Сай сөрәсең, – диде Әхәт башын селкеп. – Сай!* А.Гыйләҗев

**САЙ** II *и. махс.* Чабатада: башны кайтарып (үреп) бетергәннән соң колаксага кадәр салынган юкәләрнең берсе. *Дүрт сайлы чабата. Сай салу*

**САЙГАК** I *и.* Идән, түшәмә итеп тезеп җәелгән такталар һәм шул такталарның берсе. *Гәрәбәдәй сап-сары сайгакларга басарга кыймады булса кирәк.* Г.Галиева. *Бераздан, күз ияләшә төшкәч, күрделәр: идән сайгакларының яртысы юк, алар урынында караңгы баз авызы ыржаеп тора.* Р.Батулла. *Кыргычлап юып чыгарылган сайгаклар үзләренең табигый саргылт төсен кайтарырга азапланып яталар иде.* Р.Зәйдулла

2) *диал.* Идән. *Айгыр ябыла торган сарайның сайгак тактасын алыштырдык.* Ф.Хөсни. *Әнисе, эшкә киткәндә, Әбүзәргә мунча сайгагына бер такта ышкылап куярга кушып киткән иде.* А.Тимергалин

**САЙГАК** II *и. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан куштояклы, кабарып торган борыны хортумны хәтерләткән күшәүче дала хайваны; антилопаның бер төре. *Бу тирәдә, күрәсең, җәйраннар һәм сайгаклар бар иде.* Н.Фәттах. *Сайгаклар, ризык эзләп, бер даладан икенче далага күчеп йөриләр, ягъни күчмә тормыш алып баралар.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр. *Сайгак мөгезе*

**САЙГАКЛЫК** *с.* **1.** Сайгак ясарга яраклы яки шуның өчен дип билгеләнгән (такта тур.). *Сайгаклык агач сөйләшергә дип, Айсинә күрше авылда гына урнашкан урманчылык хуҗалыгына китте.* Н.Көбәш

**2.** *и. мәгъ.* Сайгак материалы (такталар һ.б.). *[Сәлим:] – Быел күпмедән түлиләр соң? – Сайгаклыклар өчен бишәр тиен, юкалары – өчәрдән.* М.Галәү. *Алган бурабыз тора, түбә калае, түшәмлек-сайгаклык – барысы да әзер, өй бетерәсебез бар.* Ф.Хөсни

**СА́ЙДА** *и. саам. зоол.* Тәрәччәләр семьялыгыннан эре диңгез балыгы

**СА́ЙДИНГ** *и. ингл. тех.* Биналарны тышкы яктан бизәү һәм зарарланудан саклау өчен пластик, калай һ.б.ш. тышлау материалы. *Әйе, мин бакчада түбә дә яптым, өйнең тышын сайдинг белән тышладым.* Шәһри Казан. *Мәчет сайдинг белән тышланды.* Безнең гәҗит

**СА́ЙКА** *и. фин. зоол.* Тәрәччәләр семьялыгыннан гәүдәсе койрыгына таба бик нык тарая барган диңгез балыгы. *Тәслимә буфетында алты ящик төрле эчемлек, ике капчык сайка, бер ящик «Беломор», ике ящик «Прибой» бар икән.* М.Мәһдиев

**САЙКАЛ** *и. гар.* Өслекнең яктылыкны чагылдыру үзлеге, ялтыравык, ялтырау. *Әбүгалисина --- Сәмәркандның уң ягында ике так бина кыйлды, мәрмәрдән сайкал биреп.* К.Насыйри. *Сарымайдай эр, җаным, И күңлемнең сайкалы; Бакчы, күрче: бишеккә Әкрен генә ай карый.* Г.Тукай

**САЙЛАНДЫК** *и.* **1.** 1) Бериш әйберләр арасыннан яхшыракларын сайлап алганнан соң калган, түбәнрәк сыйфатлы нәрсә; калдык

2) *сир.* Нинди дер бериш әйберләр арасыннан сайлап алынган өстенрәк сыйфатлылары. *Остаруы җитте кибетченең: яңа товар кайтса, нәчәлство хатыннарын чакырып бүлешәләр дә, сайландыктан калганнары авыл кешеләренә.* Яңарыш

**2.** *с. мәгъ.* Башка ишләрен сайлап алып бетергәннән соң калган. *Туфракны эшкәртү белән үк кишер, петрушка, укроп, редис, салат, шпинат, борчак, кызыл чөгендер, орлык суганы чәчәләр, кыяк өчен сайландык суган, башлы суган өчен орлыклык (чемчек) суган, сарымсак, иртә өлгерүче ак башлы кәбестә утырта башлыйлар.* Өмет. *Сайландык такталар*

**САЙЛАНМА** *с.* Ишле нәрсә арасыннан өстенрәк дип табылган, иң яхшы дип каралган. *Бу очрак турында хәтта Аетта туып-үскән күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең яңа ике томлык сайланма әсәрләрендә дә тасвирлама басылды.* Безнең гәҗит. *Сайланма хезмәтләр. Сайланма лирика*

**САЙЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сайлау** I. *Ул алга китә алмый җәфа чиккән колхозның председателе итеп сайланган иде.* Н.Гыйматдинова. *Аннан соң тагын ике тапкыр сайланып, бүгенгәчә республика белән идарә итә.* Безнең гәҗит

2) Артык озак, бик җентекләп сайлау. *Сөйләшүләр авыр бара, хуҗа сайлана, юри суза, чөнки йортны сатып алырга теләүче бүтәннәр дә табыла.* Ә.Еники. *Таңчулпан – ханның иң яраткан кызы икән, кызның кулын сорамаган егет калмаган, ә ул һаман сайлана икән.* М.Хәбибуллин. *Иң гаҗәбе: сайлана иң карт.* Р.Зәйдулла

**Сайлана башлау** Сайланырга тотыну. *– Торырга җирең дә булмасын, тулай торакта бәхетле гаилә төзеп, рәхәтләндереп яшәү мөмкинме соң! – дип кырт киссә, инде бу яктан тормышын көйләп җибәргәч, артыгы белән сайлана башлады.* Ф.Яхин

**Сайланып йөрү** Гел, һәрвакыт сайлану. *Ә үрдәкләр тирән елга кирәк дип сайланып йөрмиләр.* Г.Галиева. *Өйләнергә вакыт ахры, Сайланып йөрмәм юкка.* Г.Хәйруллин

**Сайланып килү** Күптәннән һәм даими рәвештә сайлану. *Моңарчы ачык тавыш юлы белән сайланып килгән Бушбугазовка «әлтернәтивә», «яшерен тавыш» сүзләре ток тоткандай тәэсир итә иде.*Ф.Дәүләтбаев

**Сайланып тору** Һаман да сайлану. *Шуңа сайланып торырга башына да килмәде.* Г.Мирһади. *Немец солдатлары шакыраеп каткан кыска кунычлы күн итекләреннән Мәскәү бусагасында карлар какканда, солдатның нинди икәнлегендә сайланып торырга вакыт калмаган иде инде.* З.Зәйнуллин

**САЙЛАНЫШ** *и.* Сайлау I (*1 мәгъ.*) һәм сайлану (*1 мәгъ.*) процессы, шуның нәтиҗәсе. *Гомумән, табигый сайланыш законнарын онытып бетермичә, эш мөнәсәбәтләре билгеләнгәнчә, башкалар куйган чиннарга карап, шуңа табынып*

*яшәү нинди ансат бит ул!* А.Гыйләҗев. *Әмма барысы да шулай очраклы гына икән, нигә соң генетик сайланыш дигән әйбер бар?* Ватаным Татарстан

**САЙЛА́У** I *ф.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса өстенрәк сыйфатларга ия булганын яисә күңелгә ятышлырагын аерып алу, өстен дип табу. *Бераз буш вакытыңны туры китереп безгә әйт, бергә чыгып күлмәклек сайларбыз.* К.Тимбикова. --- *әнкәем яшел калайга эре-эре бизәкләр төшерелгән сандыгы өстенә иелгән дә киемнәр сайлый.* Н.Гыйматдинова

2) Тавыш биреп, берәр оешма яки орган төзү, шуларга әгъза итеп яки җаваплы хезмәт урынына үткәрү, кую, билгеләү. *Ә авыл советы башлыкларын мин дә сайладым.* М.Хуҗин. *Заманы шул: сайрамасаң – Сайраталар икән шул! Сайласаң-сайламасаң да Сайлаталар икән ул.* Мөҗәһит

**Сайлап алу** Ныклы бер карарга килеп сайлау. *Ә үкенеп нишлисең, әти белән әнине сайлап алып булмый.* Р.Зәйдулла. *...Актёр калын портфелен ачты да аннан машинкада басылган бер кочак рольләр тартып чыгарды, арадан берсен сайлап алды.* Ф.Әһлиуллина

**Сайлап йөрү** к. **сайлап тору**

**Сайлап кую** Тиз арада сайлау эшен башкару. --- *менә көймәбез, кылычкамышларны ерып, ярга барып төртелә, шыбырдашып, шаулашып, ярга коелабыз, тиз арада утрауның губернаторын сайлап куябыз.* А.Гыйләҗев. *Авылдашларының намусы сафлыгына ышанган ташлытаулылар бертавыштан сайлап та куйдылар үзен.* Г.Минский

**Сайлап тору** Озак вакыт дәвамында яки хәзерге вакытта сайлау. *Кол егетне бикә, ахрысы, чын күңелдән яратты һәм, йолага таянып, икенче ир сайлап тормады.* Н.Фәттах

**Сайлый башлау** Сайларга тотыну. *Николай Николаевич алгысыган күңеле белән үзенә «әйбәт җылы куыш» сайлый башлый, хатыны белән шул турыда киңәшергә дә исәп итә, ләкин берничә сәгатьтән соң ук ул уйлары челпәрәмә килә.* Г.Ахунов

**САЙЛА́У** II *и.* 1) Сайлау I (*1 мәгъ.*) гамәле. *Икенче җитди эше аның бала табу йортын сайлауга бәйле иде.* Г.Ахунов

2) Сайлау I (*2 мәгъ.*) эше, процессы, акты, кампаниясе. *Авылыбызның иске кәнсәләр бинасының сайлаудан сайлауга гына мунчала күргән идәннәрен кыргычлап юдылар.* А.Хәлим. *Таң белән сайлау бүлмәләренә гавам бәреп керде.* Ф.Бәйрәмова. *Иң демократик сайлау системасы дип, ничә еллар буе халыкны ышандырмак булдык.* Ш.Галиев

3) Сайлауга катнашу. *Сайлау хокукы. Сайлау яшенә җитү. Сайлау таныклыгы*

**САЙЛАУЛЫ** *с.* 1) Сайлау-сайлану тәртибендә генә билгеләнә торган (хезмәт урыны һ.б. тур.). *Сайлаулы вазифа. Сайлаулы муниципаль эш урыннары*

2) Сайлау I (*2 мәгъ.*) юлы белән тупланган кешеләрдән төзелә, оештырыла торган. *Сайлаулы органнар. Сайлаулы оешмалар*

**САЙЛАУЧЫ** *и.* Сайлауда катнашучы яки шуңа хокукы булган кеше. *Бер сайлаучы – бер нокта, ике сайлаучы – ике нокта. Биш нокта – биш кеше тавыш биргән.* М.Мәһдиев. *Берничә атнадан ул булачак сайлаучылары белән очрашуга киләчәк.* Ф.Баттал

**САЙЛЫК** *и.* 1) Сай урын (суда). *Алар хәзер яр буенда, ярым сазлыкның түмгәкләре арасында чүпләнеп йөриләр, сайлыкта җим эзлиләр, инешкә кереп коенып чыгалар да төзәтенәләр, каурыйларын аралыйлар.* Г.Бәширов. *Өч яктан су тирән, яры да текә, ә бер яктан үтә күренмәле сайлык сузыла иде.* А.Тимергалин

2) Сай I булу. *Инде хатыннан күпме эләкте дә, начальникларым күпме сүкте шул хәтер сайлыгы аркасында!* Ф.Баттал

**СА́ЙРА** *и.* Саргансыманнар отрядыннан Тын океанда яши торган вак тәңкәле диңгез балыгы. *Сайра уылдыгы*

**САЙРАР** *с.* Сайрый торган, сайраучы. *Күрше куакта сайрар кош өзелепөзелеп тиңен үз кырына чакыра.* М.Хәбибуллин. *Мөхәммәтнур җырлый башласа, хәтта сайрар кошлар да, сайрауларыннан туктап, аны тыңлый икән.* Г.Галиева

**САЙРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сайрау** I

2) *күч.* Бик оста уйнау (уен коралында). *Сайрат, сайрат гармуныңны, Җилкенсеннәр яшь кызлар.* Г.Насрый. *Риҗал курай сайрата, Ләбип кубыз гыжылдата. Нури исә, үзе кашык суга, үзе дирижёрлык итә, үзе басып торган җирдән бии-бии башлап җырларга керешә.* Р.Мөхәммәдиев. *Яңа малай баянны бик яхшы сайрата икән.* Ф.Шәфигуллин

**Сайрата башлау** Сайратырга тотыну. *Миргалим абзый, яшьлеген, «Галия» мәдрәсәсендәге кыллы оркестрда уйнап йөргән елларын искә төшереп, мандолинасын сайрата башлады.* Р.Мөхәммәдиев

**Сайратып алу** Беразга гына сайрату. *Барласыч бу юлы үзен акыллы итеп күрсәтте: шунда ук тел сандугачын сайратып алды.* Ф.Яхин

**Сайратып җибәрү** *к.* **сайрата башлау**. *Ә соңыннан, башын ия төшеп, гармунына сыенып, аның күреген сузар да и-и-и сайратып ла җибәрер иде...* Ф.Әһлиуллина. – *Әйдә әле, бер сайратып җибәр, илләр гаҗәпкә калсын!* – *диде, батырчылык итмәдем.* Ф.Яхин. *Һәм берни булмагандай, тагы да күтәренкерәк күңел белән баянын сайратып җибәрде.* Р.Мөхәммәдиев

**Сайратып карау** Булдыра алуалмавын сынау, тикшерү өчен сайрату. *[Мәче Сандугачка:] Шуның өчен мин сине тотып, үз алдымда сайратып карамакчы булган идем; селкенмә, тиберченмә, кошчыгым, мин сине бөтенләй үк ашамыйм әле; курыкма, сайра әле, дустым.* Г.Тукай

**Сайратып кую** Бер генә тапкыр яки бик аз гына итеп сайрату. *Тирәләй тезелгән утыз-кырык күз эшне күзәтәләр, киңәшләр бирәләр, вакыт-вакыт мәдрәсә тын була, тик күзәтү белән артык мавыгу аркасында йомшап киткән борыннар гына «черт! черт!» итеп «чикерткә сайратып» куялар.* Ә.Фәйзи

**Сайратып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер сайрату. *Абый тальянын чут-чут китереп сайратып тора*

**САЙРА́У** I *ф.* 1) Матур аһәңле, күңелгә ятышлы сызгыру, чутылдау авазлары чыгару (кошлар тур.). *Ишәк бакырганда, сандугач сайрамас.* Мәкаль.

*Һавада тургай сайрый, ә күңел тулы сагыш.* М.Хәбибуллин. *Басу өстендә бытбылдыклар таралган, чутылдатып, өздереп-өздереп сайрыйлар.* К.Тимбикова. *Елганың теге ягында кояш инде дилбегә буе өскә менгән, бөтен табигать нурда коена, кошлар сайрый, үлән арасында чикерткәләр черелди.* Р.Зәйдулла

2) Кычкыру; төрле авазлар чыгару (бөҗәкләр, бакалар тур.). *Тышта чикерткәләр сайрый. Әчтә Фоат тырылдый.* Р.Сәлим. *Менә шулар [бакалар], аеруча тын җылы кичләрдә, көтүләре белән су читенә җыелып, тотыналар төрлесе төрлечә «сайрарга»!* Ә.Еники. *Мич арасында өзелергә җиткән нәзек тавыш белән чикерткә сайрый.* Ф.Әһлиуллина

3) *күч.* Бик матур җырлау; ягымлы итеп һәм бик оста сөйләү. *Кызый, торган саен кыюлана барып, тагын да шәбрәк сайрарга тотынды.* Г.Бәширов. *Сайланганда сайравыннан Халыкның китте һушы. Бүген менә баш кашыйбыз: Нәтиҗәләре – шушы.* Мөҗәһит

4) *күч. хуплм.* Кирәктән артык озак, күп сөйләү, такылдау. *Моны аңа үзен озатучы сакчы сайрады.* М.Хәбибуллин. *Бик дөрес сайрыйсың, әбекәчкәем!* С.Поварисов

5) *күч.* Төчеләнеп, ярарга тырышып сөйләү. *Ә мин, күрми күргән, көндез чыра яндыра башладым, җитмәсә хан кызына гашыйк булдым, дип сайрыйм.* М.Хәбибуллин. *Ә теге чакта, ди йөрәк сыкрап, ә теге чакта син башкача сайрый идең бит!* Р.Йосыпова. *Сикереп тордым да: «Каян беләсез аны? Бергә эшләп караганыгыз бармы әллә? Берне сайрыйсыз!» – дип кычкырдым.* А.Гыйләҗев. *Ә Шәрук белән үзем аңлашырмын. Болай сайрамас бүтән.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Аһәңле авазлар чыгару, көй яңгырату. *Гармун телләре аның кулында сайрап кына тора.* Р.Ишморат. *Айлы төннең салкын һавасында, калынлынечкәле авазлар чыгарып, кайдадыр чана табаннары сайрый.* Г.Бәширов

**Сайрап алу** Бер вакыт эчендә генә сайрау. *Урманның әле бер ягында, әле икенче башында кошлар сайрап алуын, колак төбендә бертуктаусыз бөҗәкләр безелдәвен исәпкә алмаганда, табигать бер кайгысыз тынлыкта яшиде.* Г.Гыйльманов

**Сайрап җибәрү** Сайрый башлау. *Сандугачым, сайрап җибәр, Талларың тамырлана. Салкын сулар эчеп кенә, Йөрәгем сабырлана.* Җыр. *Песнәк өздереп сайрап җибәрә.* А.Гыйләҗев. *Чит җирләрдә ни хәлләр бар? Я, сайрап җибәр, тургай.* Р.Муллин

**Сайрап йөрү** Гел, һәрвакыт сайрау. *Моның нигезендә «үлгән затларның җаны шул каен агачларында яки шунда сайрап йөргән кошларда гәүдәләнә» дигән бик борынгы караш ята.* Ф.Урманче

**Сайрап калу** Бер эш-хәлгә кадәр сайрап өлгерү яки сайрап тору. *Сандугачлар сайрап калды, Син очып киткән идең. Төшләремдә күрә-күрә Мин сине көткән идем.* Җыр. *Галимҗан Ибраһимов соравы буенча, кыз тиз-тиз генә барын да сайрап калырга ашыкты.* С.Поварисов

**Сайрап куюю** Бер мәртәбә яки сирәк кенә сайрау. *Якында гына шәфәкъ чыпчыгы сайрап куйды.* Ф.Әһлиуллина. *Ара-тирә генә саташкан урман тургае сайрап куя, яисә шәүлегәннең шомлы тавышы ишетелеп китә.* Г.Гыйльманов. *Сандугачлар төн һавасын тетрәтеп сайрап куя.* Г.Харис

**Сайрап тору** Һәрвакыт, даимән сайрау. *Айлы кичне яратам мин, Кошлар сайрап торганда. Ай тулганда, җил тынганда, Син янымда булганда.* Ә.Ерикәй. *Бәхет кошым булып сайрап торсаң иде Оябызны корган төбәктә.* Г.Гыйльманов. *Кош булып барырмын сиңа, Җаныңда тирәк булса. Өзлексез сайрап торырмын, Җаныңа кирәк булса.* К.Шәфыйкова

**Сайрый башлау** Сайрарга тотыну. *Кайдадыр кошлар сайрый башлады.* Г.Гыйльманов. *Кичке чәйне эчеп йокларга җыенганда, бака тагын сайрый башлады.* Р.Батулла. *Менә ничек сайрый башлады безнең сандугачыбыз...* Х.Ширмән

**Сайрый бирү** Һаман сайрау, бернәрсәгә карамастан сайрау. *Кайберәүләр, чытык чырай белән көлемсерәп, кызыштырмау ягын тоттылар: – Кирәкмәс, әйдә сайрый бирсен...* Ш.Камал. *Тел чарлаудан башка эше юк: өлкә үзәгендә кем нинди урын били, кемне эшеннән алганнар, кемне күтәргәннәр – шулар хакында сайрый бирә.* Ч.Айтматов

**САЙРА́У** II *и.* Кошларның күңелгә ятышлы авазлар чыгарып чыркылдавы. *Сагышлы чыга сандугачның сайравы.* М.Хәбибуллин. *Карагыз әле, бүген тургайларның сайраулары да бөтенләй башкача бит.* Г.Галиева. *Сандугач та үз сайравына фәлсәфи мәгънәләр салмый, аның максаты анык: ул былбыл кызын кавышырга чакыра...* Р.Зәйдулла

**САЙРАШУ** *ф. урт. юн.* 1) Барысы берьюлы сайрау **1.** (*1, 2*). *Мич арасы сандугачлары – чикерткәләр – уздырышып сайраштылар.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Күңелле, күтәренке кәеф белән сөйләшеп вакыт уздыру. *Утырыйк әле әйдә, сеңелкәй, Туганнарча сайрашып кына.* Х.Туфан. *Ә инде Галимҗан белән һаман-һаман сайрашып утыруларын ата һәм ана изгелеккә, яхшылыкка юрый.* С.Поварисов. *– Кара, нәрсә сайрашалар болар монда икесе генә? – диде Фәтхи.* Л.Шафикова

**САЙТ** *и. ингл. информ.* Шәхси зат яки оешманың компьютер челтәрендә бер адреска берләштерелгән электрон документлар җыелмасы. *Бер сайт милләтне алга җибәрә алмый.* Безнең гәҗит

**САЙФИЯ** *и. гар. иск.* Гадәттә җәен вакытлыча яшәү өчен салынган йорт, дача. *Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе.* Г.Тукай. *Сайфиягә ерткыч керә калса, Алабай тази ялгызы гына да, бүреңне генә түгел, арысланыңны да ботарлап ташлаячак.* М.Хуҗин

**САК** I *с.* **1.** 1) Игътибары көчле, сизгер; уяу. *Ләкин аның күпьеллык тәҗрибәсе сак булырга өнди, катлаулы вакыйгаларда чарланган сизгерлеге тагы да үткенләнә, тагы да нечкәрә төшкән иде.* А.Расих. *Бирегә сак булырга кирәклеген әни дә кисәтеп куйган иде.* Р.Зәйдулла. *Торна – бик сак кош.* Кошлар

2) Аеруча сизгер, үткен (тоюю-сизү органнары тур.). *Шулай утырганда, Хәлимнең сак колаклары ат абзарының ишеге шыгырдап ябылганын ишетте.*

Г.Гобәй. *[Солдатның] күзләре бик сак.* Ф.Кәрим

3) Милекне саклап кына сарыф итүче, кадерләп тотучы, сакчыл. *[Паёкны] көне буена җиткерергә кирәк. Берәүләр түзмиләр, берьюлы ашап бетерәләр. Саграк кешеләр өч кисәккә бүләләр дә, бер өлешен иртән ашап, калган ике өлешен көндезгә һәм кичкә калдыралар.* Г.Әпсәләмов. *Зәкия яшьяшь булса да, бик сак, сабыр кыз булып чыкты.* Г.Галиева

4) Бүтәннәрнең игътибарын җәлеп итмәскә тырышып, саклык белән эшләнә торган (эш-хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Без, автоматларны корып, сак адымнар белән тавыш-тынсыз гына алга барабыз.* Ә.Айдар. *Менә хәзер дә скважина авызы янына баскан Кәримне авыруга бик җитди операция ясый диярсең: җир астыннан кран күтәртеп чыгарган һәр штанганы сак хәрәкәтләр белән әйләндергәләп, бөртекләп күзеннән кичерә.* Л.Шафикова

5) Саклыкны белдерә торган, уяу (эш-хәл, сөйләм, тавыш һ.б. тур.). *Гаяз, берәрсе тыңлап тормасын дигән төсле, сак тавыш белән колагыма пышылдады.* М.Әмир. *Әнисенең болай да сак йокысын бүлеп, төннәрен урамга чыгарга аның йөрәге кушмады.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Сакланып, саклык (*1–4 мәгъ.*) белән, сак (**1.**) рәвештә. *[Сәлим] адымнарын шундый әкрен һәм шундый сак атлый, әйтерсең кош тотарга килүче чуар песи.* Г.Әпсәләмов. *Монда алар аеруча сак кыландылар: кычкырып сөйләшү, көлү, тояк тавышлары – барысы да тынып калды.* Н.Фәттах. *Таксины соң чиктә генә ала Идрис, Диләкайгысы белән фатирсызлык аны акчаны сак тотарга өйрәтте.* А.Гыйләҗев

**САК** II *и.* 1) Саклау, каравыллау өчен куелган, билгеләнгән кеше, төркем яки коралды көч. *Якын-тирәдә бер генә сак та, бер генә уяу кеше дә күренми иде.* Н.Фәттах. *Улын сакка куя да, «берәр кеше күренсә, тамак кырырсың» диеп, ат күмелерлек таллыклар, --- ат күзгалаклары артына яшеренеп, агымсуы аяк йөзенә генә чыгып торган елгада су коена.* А.Хәлим

2) Сакчы хезмәте һәм вазифалары; сакчылык посты. *Егетләр, сафка тезелмичә, вагоннарына юнәлделәр. Аларның урынын көндез сакка куела торган кечкенә отряд алды.* Ш.Усманов. *[Галимҗан] Сакта торган солдат кебек басып торды.* С.Поварисов. *Ул, ягъни [Хәмитнең] уртанчы малае, армиядә чакта Кремль сагында хезмәт иткән.* Ә.Еники

3) *тарт. форм.* Саклау күренеше, саклау процессы. *Таң беленеп килгәндә, тынычсыз полк, конвой сагы астында товар вагоннарына ябылып, билгесез якка җибәрелде.* К.Нәҗми. *[Врач булып эшләү] Кеше гомере сагында торучы фидакарьләр хезмәте.* Р.Ишморатова

4) Алдагы көнгә, киләчәккә дип саклана торган нәрсәләр; җыелган акча; запас. *Саклаганның сагы бар.* Әйтем

◊ **Сак астына алу** Кемне дә булса ирегеннән мәхрүм итү; кулга алу

**САК** III *и. фр. иск.* 1) Юлда капчык урынына йөртелә торган зур букча

2) Озын һәм киң хатын-кыз пальтосы. *[Гайни:] Биби абыстай, әле минем сиңа әйткәнем юк бит, мин бер сак тектерергә бирдем.* Г.Камал. *Каракүл сак*

**САКА** I *и. диал. вет. к.* **сакау** II

**САКА** II *и. зоол. к.* **сакакош**. *Сака йомыркасы*

**САКАКОШ** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан төрле төстәге матур каурыйлы сайрар кош; *русчасы:* **щеглёнок**

**САКАЛ** *и.* 1) Ирләрнең иягендә һәм яңагында үсә торган чәч. *– Утәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек ап-ак кылдай сакалын селкетеп.* Ә.Еники. *Сәрвәретдин җирән мыегын, кыска җирән сакалын сыпырып куйды да, остазының урынсыз соравына ачуы килеп, йөзен чытты.* С.Поварисов

2) Кайбер хайваннарда һәм кошларда тамак яки томшык асты турысыннан салынып тора торган озын төкләр яки каурыйлар. *Кәҗәнең туганда ук сакалы була.* Әйтем. *Мин кәҗәдән җитез: йөгерәмен бик тиз. Аны куып тоттым, «әбәк!» диеп суктым. --- Акайтты ул күзен, тырпайтты мөгезен, сакалын селекте, мине куып китте.* Р.Харис. *Тузгыган йөнтәс башы, җилкәсеннән үк үсә башлап, үңәченә салынып торган дәү, куе сакалы, озын муены астыннан тезләренә кадәр асылынып төшкән учма-учма кыргый ялы, сыртында манара төсле калкып торган тыгыз өркәчләре һәм, шуларның барысы өстенә, кыска гына койрык очы – һәммәсе кара төстә.* Ч.Айтматов

◊ **Сакал сыпырып калу** *к.* **бит сыпырып калу**. *[Әскәрнең] баладан бәхете булмады: кызганычка каршы, бер малай белән сакал сыпырып калырга туры килде.* А.Гыйләҗев

**САКАЛА́У** *ф. к.* **сакаулау** II

**Сакалап тору** Соңгы вакытта сакау белән авыру

**САКАЛБАЙ** *и. сөйл.* 1) Зур сакаллы кеше. *Хәзер инде алар бу сакалбайның Хозыр-Ильяс түгел, Солтанмораттагы Гыйрфан мулла малае икәнлеккә ныклап ышандылар.* С.Поварисов. *Кичә кич кенә бу – автобус тукталышында бер сакалбай кочагында тора иде. Ә бүген менә Таңнур каршында чытлыклана кыз.* М.Шаһимәрдәнов. *Сарман сакалбае, шаярган булып, күңелгә чынлап та чебен кертте инде әллә, чукынган!..* Г.Мөхәммәтшин

2) Кәҗә. *Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк». Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».* Г.Тукай. *Унунбиш адым да читкә китә алмадылар, янәшәдәге куаклар артыннан унлап сакалбай йөгерешеп чыкты.* Г.Гыйльманов. *Иртүк сакалбайны Тай чокырына аптөшерсең, тәмле үлән чемченер.* Н.Гыйматдинова

**САКАЛБИКӘ** *и. окказ.* Кәҗә. *Бик тә сөтле кәҗә булып чыга сакалбикә.* Р.Батулла

**САКАЛДЫРЫК** *и. этногр.* Ияк астына бәйләнеп куела торган вак тәңкәләр тезелгән тасмадан гыйбарәт татар милли кием элементы

**САКАЛЛЫ** *с.* 1) Сакалы булган, сакал үстергән. *Һәр сакаллы берәр төк бирсә, күсә дә сакаллы булыр.* Мәкаль. *Өстенә озын тун киеп, билен киң каеш белән буган, сирәк сакаллы, озын, чандыр Куник карт аларга юл өйрәтте.* Н.Фәттах. *Бер биш минуттан дежур-*

*ный, чыгып, чаңны ике тапкыр сугып ала, шуның артыннан ук сакаллы кондуктор сыбызгысын чырылдатып җибәрә, һәм очтагы паровоз калын гына итеп кычкырта да --- әкрен генә кузгалып китә.* Ә.Еники

2) Урта яки өлкән яшьләрдәге (ирләр тур.). *Зурлар – сакаллы агайлар да – ташкынлы язны нәкъ элекке еллардагы кебек дәртләнеп каршыладылар.* А.Шамов. *Сакаллы шәкертләр берлән мәсҗед тулган.* Г.Исхакый. *Рабфакта төрле халык укый: үсмерләрдән башлап олы яшьтәге хатыннарга, сакаллы абзыйларга чаклы бар.* Г.Ахунов

3) *күч.* Күптәнге, әллә кайчаннан билгеле булган (хәбәр, мәзәк тур.). *Ахыр чиктә ул түзмәде: – Сакаллы яңалык ич бу! – дип куйды.* А.Тимергалин

◊ **Сакаллы башы белән** Инде өлкән яшькә җитеп, тәҗрибә, белем туплаган булуга карамастан. *Җитмәсә, ул сакаллы башы белән исәпләп чыгара алмаганны бу малай мәзәк кенә итеп әйтте дә бирде.* Г.Бәширов. *Хуҗа йөгереп чыгып, коега иелеп караса, анда үзенең шәүләсен күргән дә: – Ап-ак сакаллы башың белән баланың икмәген тартып алырга оялмыйсыңмы? – дигән.* Мәзәк. **Сакаллы сабый** *шелт.* Яше олы булып та, фикерләү дәрәҗәсе, үзен тотышы белән бала-чагага тартымрак кеше. *Аһ, кем! Ата-бабаларыбыз сакаллы сабыйлар икән, Аларны кеше дип исәпләү ялган һәм яла икән.* Г.Тукай. *Югыйсә сакаллы сабый, тапкансың икән сөйләр сүзен дә, кешесен дә, дип көләр үземнән.* Г.Мөхәммәтшин. *Сакаллы сабый режиссёрлар да курчак уены белән мәшгуль бит.* Ш.Галиев

**САКАЛ-МЫЕК** *җый. и.* Сакал һәм мыек. *Йөзен сакал-мыек басты.* С.Поварисов. *Барысы да елмаешып алдылар, сакал-мыекларын сыпырып куйдылар.* М.Хәбибуллин. *Сакал-мыеклары җиткән, күзләре акайган, үзләре шабыр тирдә.* И.Салахов

**САКАЛТАЙ** *и. к.* **сакалбай** (*1 мәгъ.*). *Тамаша тәмамлангач, Кәмитҗан белән аның янында бөтерелеп йөрүче сакалтай сәхнәгә күтәрелде.* М.Сәлимов

**САКАЛТАМЫР** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан каты озын сабаклы, куе тамырлы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **бородач**

**САКА́У** I *с.* **1.** 1) Кайбер авазларны (бигрәк тә *р, л* тартыкларын) әйтә алмый яки аларны бүтән авазлар белән алыштырып яисә бөтенләй төшереп калдырып, сүзне бозып сөйли торган (кеше һәм тел тур.). *Ул да минем укытучыгемне сизә кебек, иркәләп сөйләшә, мин шунда гына аның бераз сакау икәнлеген, «ц»ны әйтә алмаганын тоям.* А.Гыйләҗев. *Кечкенә вакытта ул бик сакау иде.* М.Мәһдиев. *– Кулыктык, – дип сүз кыстырды сакау Алмыш.* А.Тимергалин

2) Тавышы беткән, сайрау сезоны үткән (күке, сандугач кебек кошлар тур.). *Саескан тутый телен әләкләп сакау калган.* Мәкаль. *Сакау сандугач. Сакау кәккүк*

3) *лингв.* Тел очын аскы һәм өске тешләр арасына куеп, җиңелчә генә өреп ясалган, интерденталь (аваз тур.). *Кушымчадагы сакау д ны руслар [ф] дип укыганнар, шуңа күрә «скыды» этнонимы русча «скиф» булып кабул ителгән.* М.Зәкиев. *Минзәлә сөйләшендәге сакау з. Гарәпнең сакау әйтелешле сә һәм зәл хәрефләре. Башкортча сакау з һәм с авазлары*

**2.** *рәв. мәгъ.* Кайбер авазларны бозып яки бер аваз урынына икенчесен әйтеп. *Сакау сөйләшү. Авазларны сакау әйтү*

**3.** *и. мәгъ.* Авазларны бозып сөйли торган кеше. *Аксак утырмас, сакау тик тормас.* Мәкаль

**САКА́У** II *и. вет.* Атларның йоткылык өсте лайлалы тышчасы ялкынсыну, казналык асты лимфа төеннәренең үлекләве белән характерлана торган кискен йогышлы авыру. *Сакау антивирусы. Сакау шеше. Сакау чыккан колын*

**САКАУЛАНУ** *ф.* 1) Сакауга әйләнү. *Шәрифҗан абый ни өчен сакауланган? Аның һичкайчан болай тотлыгып сөйләгәне юк бит!* Г.Иделле. *Янчыгына ниндидер кызганулы караш ташлый, аны кире тыкканда, авызына су җыелып, тагы да сакаулана, кайвакытта бөтенләй ялгышып сөйләп куя.* М.Мәһдиев

2) Сакау (*1 мәгъ.*) булып кылану, сөйләү. *Бала сакаулана дип, ана сакауланган, икесе дә сакау булганнар, ди.* Әйтем. *Аларның Гәрәйнур исемле биш яшьлек малайлары бар, ул туганнан бирле читтә йөреп, татарча өйрәнә алмый калган, сакауланып русча сөйләшә.* Г.Ахунов. *Анда бит гел сакауланып укыйлар, с димиләр, ц диләр.* М.Мәһдиев

3) Сайраудан туктау (кошлар тур.). *Бака кычкыра башласа, сандугач сакаулана, дип әйтәләр бит халыкта.* Р.Низами. *Сакаулана сандугач, Салкын су эчә-эчә.* Р.Бәшәр. *Ул инде артык сайрый алмады, чөнки куркуыннан саташкан, сакауланган иде.* Р.Гали. *Питрауда күке сакаулана*

**Сакаулана бару** Торган саен ныграк сакаулану

**Сакаулана башлау** Сакаулык барлыкка килү

**Сакауланып бетү** Тәмам сакауга әйләнү

**САКАУЛА́У** I *ф.* Сакау тел белән сөйләү. *Сакаулабрак булса да, грек сүзләрен урынына куеп, дөрес әйтте гуннар ханы.* М.Хәбибуллин. *– Малайлаг, – дип хахылдап көлергә кереште ул, [р] авазына сакаулап, – кайсыгыз зиңә, шул пәкене ала!* Ш.Алпар

**САКАУЛА́У** II *ф.* Сакау чире белән авыру (атлар тур.). *Кырыкмыш сакаулаган*

**Сакаулап тору** Соңгы вакытта сакау белән авыру

**САКАУЛЫК** *и.* Сакау (I) булу, сакау кешегә яки кошка хас сыйфатлар. *Өйдәгеләр аның инде бик аз калган сакаулыгын да яшерергә тырышып әйтелгән сүзләрен эш аралаш көлешә-көлешә тыңлап тордылар.* Г.Гобәй. *Хәтта шул сакаулык та бизи аны, үтә нык килешә.* А.Гыйләҗев

**САКВОЯЖ** *и. фр.* Бикләнә торган һәм гадәттә күннән ясалган юл сумкасы. *Сәйфи капкадан чыгып китәм дигәндә генә, кулына саквояж тотып, ак халатлы һәм ап-ак чырайлы кеше керә.* З.Хәким. *Муллануր Московский урамында яшәүче әнисе белән күрешеп, аның битеннән үпте дә, чәй дә эчеп тормастан, инде кичке караңгы төшсә дә, саквояжын калдырып, өйдән чыгып китте.* А.Расих

**САКЕ** *и. яп.* Японнарның дөгедән ясалган милли исерткеч эчемлекләре, дөге аракысы. *Россиядә – арыш, бодай, арпа аракысы; Америкада – кукурузДан виски; немецләрдә – бәрәңгедән шнапс; кытайларда – солыдан хашина; японнарда – дөгедән саке.* Ватаным Татарстан. *Куәтле саке. Саке эчү*

**САКЛАВЫЧ** *и. к.* **саклагыч 1.** (*2 мәгъ.*). *Тормоз контурларын көйләп, саклавычны алыштырып куйганнан соң, электроник машина эшкә әзер иде инде.* А.Тимергалин. *Стартер чорнауларын саклау өчен, җиңел эри торган саклавыч куела.* Тракторлар һәм автомобильләр

**САКЛАГЫЧ** *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса саклау урыны, бүлмәсе һ.б.ш. *Ит саклагыч. Азык саклагычны чистарту*

2) *тех.* Нәрсәнең дә булса зарарыннан саклый торган җайланма. *Аз сүзле итеп яратылган машинабыз туктау әмәлен үзе тапты (моның өчен аңа тышкы дөньядан аерылу, һич югында саклагычларны яндырып өзү генә кирәк иде).* А.Тимергалин. *Компастагы саклагыч. Аппараттагы саклагыч*

**2.** *с. мәгъ.* Зарар килүдән саклый торган, шуңа хезмәт итә торган. *Саклагыч монолит конструкцияләрдә махсус бетоннар: бик авыр бетон, кызуга чыдам бетон һ.б. кулланыла.* Төзү материаллары. *Станокларга [автоматларга] саклагыч рәшәткәләр куелган.* Ә.Камал. *Саклагыч күзлек*

**-САКЛАГЫЧ** Кушма сүзләрдә беренче компоненты итеп бирелгән нәрсәне саклау өчен билгеләнгән корылманы белдерә торган икенче компонент. *Сусаклагыч. Нефтьсаклагыч*

**САКЛАНУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **саклау** (*1–9, 12, 13 мәгъ.*). *Монда кышкы айларда да кар ятмый, биш-алты градус җылылык саклана.* А.Расих. *Ул гынамы, аның балалары чит илдә укый, акчасы чит ил банкларында саклана, утырган машинасы – иномарка...* Р.Зәйдулла. *Ярты гасырдан артык җир куенында яткан киндернең болай саклануы да гаҗәп әле.* А.Тимергалин

2) Үзеңне саклау, яклау. *Колагын яткырган аттан саклан.* Мәкаль. *[Шәрәф:] Читкә җибәрүләрендә бер хәйлә булмасын дип? никадәр сакландым, шулай да ауларына төшкәнмен.* М.Фәйзи

3) Үзеңне нәрсәдән яки нинди дә булса хәрәкәттән тыю; саклык күрсәтү. *Очраган бер кеше сүзенә карап, теләсә нинди дуамал адымнар ясаудан сакланырга кирәк.* Ш.Камал. *Төркиләр гөнаһтан сакланган.* З.Мурсиев. *Эчүдән саклану*

4) Хәтердән чыкмау, гел истә тору. *Алай, нәсел кушаматы ир затларында гына нык саклана шул.* М.Хуҗин

**Саклана бирү** Бернигә дә карамастан саклану. *Соңгы елларда бу йола үзе онытыла барса да, язгы эшләрнең муллык, туклык эчендә, хәере белән башланып китүенә, игеннәрнең уңуына юрап, чәчүгә чыгасы көнне йомырка пешерү гадәте Хәдичә түтидә хәзергәчә саклана бирде.* Г.Бәширов

**Сакланып йөрү** Һәрвакыт саклану. *...Композиторның уйнавын тыңлап торганда, Галия әнә шул ерак калган якты иртәне исенә төшерде, һәм әнә шул кояшлы бәйрәмнәрнең күңел түрендә сакланып йөргән җанлы шәүләсе кинәт кенә, чишмәдәй чылтырап агыла башлады.* Ф.Әһлиуллина

**Сакланып калу** Нindидер вакыйгалардан соң саклану, югалмау. *Каян шундый вак-төякләр хәтердә сакланып кала диген, урын алып торалар ич алар анда, мине чүплиләр!* А.Гыйләҗев. *Ә Раданың күңелендә әйтеп бетергесез татлы бер хис сакланып кала.* Ф.Әһлиуллина

**Сакланып тору** Әле һаман да сакланган хәлдә булу; озак саклану. *Айны болыт каплаганга һәм ут алмаганга, йөрәкне баса торган шомлы караңгылык бәләкәйләр бүлмәсендә бик озак сакланып торды.* Г.Ахунов

**САКЛАНУ** II *и. мәгъ.* 1) Бозылмыйча, тузмыйча озак тору чоры. *Саклану вакыты*

2) Үзеңне зарар килүдән саклау күренеше. *– Һичнәрсә булмас. Әгәр дә... эшләп авырсынгансың... саклану кирәк иде, иптәш, – диде Мохтар.* Ш.Камал. *Нотфулла белән Сафаның гәбенә Мифтах карт тыгылмый, әмма шулай да дөньяларын онытып, тавышларын күтәреп җибәргәндә, саклану чаралары күрергә кирәклеген исләренә төшереп куюны кирәк таба торган иде.* Ш.Алпар

**САКЛАНЫШ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса саклану дәрәҗәсе; сыйфаты үзгәрмәү, бозылмау яки югалмау. *Кулъязма җыентыкның сакланыш дәрәҗәсе уртача.* Р.Мәрданов. *Бу – автор тарафыннан милли сакланышның, мәдәни алгарышның мөһим шарты төсендә тәкъдим ителә.* Т.Гыйлаҗев

2) Саклану ысулы, саклану рәвеше. *[Агроном] кайтарылган химикатларның сакланышы белән кызыксынды.* Ш.Усманов

**САКЛА́У** I *ф.* 1) Иминлекне, хәвефсезлекне тәэмин итеп тору. *Элек сакчылар ил чиген саклаган, төрмә каравыллаган, һич булмаса, төнге ресторанда «төрткәләп чыгаручы» булып эшләгән.* Д.Булатова. *Тауның тынлыгын саклый, ди ул, байлыгын, иминлеген саклый, ди.* Г.Гыйльманов

2) Югалу, зарар килүгә юл куймау. *Ул – гөлләрне кыраудан саклый аладыр иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Урманны яраткан, аны яклаган, саклаган кеше гомумән начарлык эшли алмый.* Ватаным Татарстан // *у.-вак. килеш. соң.* Югалу, бозылу-зарарланудан имин урында махсус тоту, асрау. *Аны [затлы сырганы] да иң әүвәл бер мәшһүр археолог өйдәге сейфында саклаган, имеш.* Р.Зәйдулла. *[Гобәйдулла] Чоланда нindидер төргәк тә яшереп саклый.* Н.Гыйматдинова

3) Зыян салмау, кайгырту. *Тиргә баткан атың арып беткән, Сакла үзен, салкын тимәсен!..* Һ.Такташ. *Иренең кыяфәтен күргәч, хатыны: «И картым, картым, үзеңне бигрәк сакламыйсың инде», – дип, яратып кына шелтәләп алды.* Ф.Яруллин

4) Нинди дә булса әйберне билгеле бер максат белән сарыф итмичә тору. *Әкрәм каринең кара көнгә дип саклап тоткан запас икмәге юк иде.* М.Галәү. *[Уракны] Ничә еллар, ничәмә еллар буе сакладым бит, ә!* Г.Мөхәммәтшин

5) Сак файдалану, кадерләп тоту (кием-салым, корал-дирбияне һ.б.ш.). *[Әнисе:] Апаң киемен саклап кия, син алай итмисең шул.* Ф.Әмирхан. *[Эш*

*коралын] сорау гына җитми, барын саклый белергә кирәк.* К.Тинчурин // Әрәм-шәрәм итмичә файдалану, бәрәкәтләп тоту (азык-төлек, акчаны һ.б.ш.). *Әйт Коненкога: рөхсәтсез атмасын, патронны саклап тотсын.* И.Гази

6) Истә тоту, хәтерләү, онытмау (күңел, хәтер тур.). *Безнең хәтер кешеләрне аерылышу вакытында ничек күргән булса, шул хәлдә саклый.* Ә.Еники. *Халыкта сакланган истәлекләр буенча Г.Кандалый урта буйлы, җиңел сөякле, хәрәкәтчел, төскә-биткә коңгырт, зәңгәр күзле, кара чәчле кеше булган.* Кызыл таң

7) Белдермәү, сиздермәү, сөйләмәү (серне һ.б.ш.). *Сания белән язышкан сүзләрне Исхак үз иптәшләреннән дә, апаларыннан да бик тырышып яшереп саклый иде.* А.Гыйләҗев. *Хатынкызга, бигрәк тә әни кешегә, гармун тартып җырлап утыру ниндидер оят бер эш кебек тоелып, бу һөнәре барлыгын сер итеп шактый озак саклады ул.* Г.Әдһәмова

8) Карап-күзәтеп тору, күз-колак булу. *Каз бибиләре сакларга иренеп, кәшәкәле, пәкеле уйнап көн үткәргән ялкау малай ---, фән кешесенең нинди булырга тиешлеген аңлап бетермәсә дә, маңгаеның киң икәнлеген хәтеренә алды.* А.Гыйләҗев. *Ишегалдында таяксыз Бер адым булмый атлап. Әтәчебез әрле-бирле Йөри тавыклар саклап.* Мөҗәһит // Кайгыртучанлык күрсәтү, карау. *Аналарны кадерләргә, сакларга кирәк.* А.Шамов. *[Әни] – мине карап, төрле бәла-казалардан саклап үстерүче, тәрбия итеп аякка бастыручы.* М.Гафури. *Бәпкәләрен саклап ак ана каз Миңа таба килә, җилкенә.* Һ.Такташ

9) Каравыллау. *Колхозда бары да эшкә ярый. Уракта булдыра алмый икән, әнә яшелчә саклар.* Г.Гобәй. *Әти әнә шул бакчаны саклау, каравыллау эшен Әнисә белән миңа тапшырды.* З.Бәшири // Сак астында тоту. *[Вәзирләр:] Алыгыз, кызлар, Бибкәй Солтанны, Сараенда саклагыз аны!* Н.Исәнбәт

10) Сагалау, яшеренеп кенә күзәтү, көтеп тору. *Күләгә беткән җирдә кояш аларны тычкан саклаган мәче кебек көтеп тора төсле иде.* А.Азимов. *Абый белән без капчыкларыбыздан бәрәңге чыгарабыз да, аны көлгә күмеп, утны болгата-болгата, бәрәңге пешкәнен саклап ятабыз.* М.Гали

11) *ирон.* Кем яки нәрсәнең дә булса янында файдасызга вакыт үткәрү. *Шунда, өендә, хатынын саклап ята инде, беләм.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Алар да, шушы ярты юлда бүленеп калып, өченче көннәрен колонна төбе саклыйлар икән.* А.Гыйләҗев

12) Булдыру, тәэмин итү (тәртипне, чисталыкны һ.б.ш.); үтәү, тормышка ашыру (әдәп кагыйдәләрен һ.б.ш.). *Әнә бер пенсионер карт чиратны сакларга тырышып караган иде дә, берни булдыралмады.* Р.Зәйдулла. *Кайгы килсә, илереп-тилереп, Халык исемен сатмыйлар, Тешне кысып, яшьне йотып, Илдә әдәп саклыйлар.* Х.Туфан. *Урдага алар йола саклап, көнчыгыш капка ягыннан килделәр.* Н.Фәттах

13) Белдерү, күрсәтү (рухи сыйфатны, халәтне һ.б.); дәвам итү, югалтмау (физик, рухи яки иҗтимагый хәлне, халәтне, сыйфатны, форманы һ.б.). *Мужик булып язам... Йөрәктә дә Англиягә ачу сакламыйм.* Һ.Такташ. *--- шушы хәлне оныта алмыйча, [Идрис] Ниса апасына хөрмәт саклады...* А.Гыйләҗев. *Шулай итеп сиздермичә генә күршемә үч сакладым бугай.* Н.Гыйматдинова

**Саклап йөрү** Һәрвакыт саклау. *Хөсәен элек-электән Маһибәдәргә аерым бер якынлык, туганлык хисе саклап йөри иде.* А.Гыйләҗев

**Саклап калу** Ниндидер вакыйгадан соң саклау. *Шул көннән башлап Габбас мулла сеңлесе Зәйтүнәгә дә, башкисәр Нәҗиягә дә, аның хурлыгына шаһит булган кызы Нуриягә дә күңелендә рәнҗеш саклап калды.* Г.Ахунов. *Беркемгә кирәкмәгән ике җанны алдагы газаплары өчен саклап калдылар.* Ф.Бәйрәмова

**Саклап килү** Күптәннән саклау һәм саклауны дәвам итү. *Авылында булса, аны шулай күмәрләр дә иде: аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп токан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул...* Ә.Еники

**Саклап тору** Озак саклау; хәзер, әле саклау. *Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле кара кәзәкие белән камчат бүреге дә килеп чыкты: карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!..* Ә.Еники. *Ләйлә аларның әйберләрен саклап торды.* А.Гыйләҗев. *Әмма дә ләкин шүрләгәнен сиздерми [солдат], пычакны шинель җиңенә яшереп саклап тора.* Г.Ахунов

**Саклап тоту** Озак итеп саклау. *Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп саклап тотар өчен бүләк итәргә тели.* Ә.Еники

**Саклап яту** Дәвамлы вакыт, озак саклау. *Чәчәргә җирең җитмәгәч, чабарга тугаең булмагач, өстеңә капланырга торган урманнан бер чыбыркы сабы да ала алмагач, нәрсә дип монда гомер буенча Зәңгәр чишмәне саклап ятасың.* Г.Ибраһимов

**САКЛА́У** II *и.* Саклау (I) фигыленең бөтен мәгънәләреннән ясалып, шушы фигыль атаган процессны, хәлне белдерә. *Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач, череп-тузып кына бетәрләр...* Ә.Еники. *Гомумән, Татарстанда балык үрчетү, балык тоту, саклау һәм сату мәсьәләләре ничек куелган?* А.Гыйләҗев

**САКЛАУЛЫ** *с.* Саклана, сак астында тора торган. *Саклаулы табигать территорияләре*

**САКЛЫ** *с. сир.* 1) Саклана, каравыллана торган. *Төлке саклы бакчага керми.* Мәкаль. *Аның мөдире Вячеслав Игрунов Мортазинны 21 айга саклы яшәүгә хөкем итү уңаеннан белдерү ясады.* Безнең гәҗит

2) Сак тота торган, саклanучан. *Олпат кеше сакчыл да, саклы да була ул.* Ф.Яхин

**САКЛЫК** *и.* **1.** 1) Сак булу (кешегә яки башка нәрсәгә хас сыйфатлар); сизгерлек, уяулык. *Кешедәге үтә саклык, куркаклыкка аптырыйсың.* Ш.Галиев. *Ачуы-ярсуы әз генә дә кимемәгән, шул ук вакытта саклык, уяулык тойгысын да югалтмаган Албуга кырын күз белән*

*генә аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торды.* Н.Фәттах. *Төнге авазлар ешаю белән саклыкны да арттырырга кирәк.* Т.Нәбиуллин

2) Саклау яки саклану хисе, уе. *Ауга чыккан чагыгызда, Саклык белән йөрегез!* Һ.Такташ. *Алинә бу кадәр саклыкны һич кирәксез дип саный иде, шулай да бәхәсләшмәде.* Х.Ширмән. *Әнә ул, без аны бик саклык белән алып кайттык.* Г.Тарханова

3) Куркынычсызлык, иминлек. *Бу эшләр үзенә күрә бер әзерлек дип исәпләнә һәм саклык йөзеннән бик яшереп эшләнә иде.* М.Галәү. *– Алар саклык чаралары күрсәләр, без дә йоклап ятмадык, – диде Фәрхетдин.* А.Расих

4) Сакчыллык. *Уйлап эшләргә, саклыкка да өйрәтә халык мәкальләре.* Фән һәм тел

5) Киләге чыккач куллану өчен әзерләнгән, җыеп куелган һ.б.ш. әйбер, запас. *Солдатлар, рөхсәтсез-сораусыз, эләккән бер әйберне тартып алып теләгәнчә файдаланырга һәм саклык азыгы булмаган йортларның актык сыерын суеп ашаудан да тартынмаска кушылып, йортларга таратылды.* М.Галәү. *Гаиләнең саклыкка җыйган акчасы*

6) *сир.* Саклау вазифасы белән махсус куелган, билгеләнгән кеше яки төркем; каравыл. *Безнең взводны иртән позиция алдына саклыкны алыштырырга җибәрделәр.* А.Таһиров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Иң кирәк очракта гына файдалану өчен билгеләнгән, калдырылган. *Саклык ашлык-фәлән дә булмаганга күрә, безнең тормышның матди ягы да [начарланды].* М.Гафури

2) Акча яки әйбер саклап тота торган. *Кәүсәрия акчаны саклык кассасына җыярга тотынды.* К.Тимбикова. *Поезддан төшкәч, юл капчыгын саклык камерасына тапшырып, Әскәр җәяүләп кенә шәһәр буйлап китте.* А.Гыйләҗев. *Рәхимнең саклык кенәгәсендә бераз җыйган акчасы бар. Ләкин ул да санаулы.* А.Расих

**САКМА** *и.* Таяк башына киертелә торган тотка; таяк чукмары, таяк башы. *Сөяк сакма. Көмеш сакма. Бизәкле сакма*

**САКРАЛЬ** *с. лат. кит.* Дини йолага бәйле; изге; кешене теге дөнья белән бәйли торган. *Беренчедән, бу – адәм баласының чисталыгын, пөхтәлеген символлаштырса, икенчедән, бередә тырнакның ниндидер сакраль, яшерен көченә ышану да чагыладыр кебек.* Ф.Урманче. *Казанга алып килгән сыннары арасында да сакраль сыннар, бурятларның нәсел саклаучы изге хайваннары бар.* Ватаным Татарстан. *Сакраль дөнья*

**САКРАЛЬЛЕК** *и.* Сакраль булу. *Йолаларның сакральлеге*

**САКС** *и.* Урта гасырлар башында Төньяк-Көнбатыш Европада һәм Британиядә яшәгән борынгы герман кабиләләре вәкиле. *Анда әйтелгәнчә, герман, дат, сакс, норвег, франк һ.б. кабиләләрнең барысы да Вотан алладан яки аның якын туганнарыннан «үрчеп киткәннәр».* Ф.Урманче

**САКСАВЫЛ** *и. бот.* Таҗгөлчәләр семьялыгыннан Урта Азиянең тозлаклы һәм комлы чүлләрендә үсә торган яфраксыз кечкенә чытырман агач. *Берәүсе икенче бер дөя йөгеннән саксавыл агачлары алып килде.* М.Галәү. *Һәр ишегалдын камыш белән саксавылдан үрелгән читән аерып тора.* Т.Кәримов. *Кәрван саксавыл, дүләнә, чаган агачларыннан торган куе чытырманлык артына кереп югалгач, Бүчек телгә килде.* В.Имамов. *Ак саксавыл. Кара саксавыл. Зайсан саксавылы*

**САКСОФОН** *и. фр. [бельгияле уен кораллары остасы А. Sахның фамилиясенә гр. phōnē – «аваз» сүзе кушылып ясалган] муз.* Парабола кебек бөгелгән көпшә формасындагы җиздән ясалган тынлы уен коралы. *Танго... Юан көмеш трубалар, зур барабан, тромбон, саксофон. Танго...* М.Мәһдиев. *Беркем дә түгел, музыкасын шушы чикерткә генә акыртадыр, берьюлы барабан кагып, саксофон кычкыртадыр кебек тоелды.* Н.Гыйматдинова

**САКСЫЗ 1.** *с.* 1) Куркыныч турында уйламаучы, саклыкны онытучы. *[Кыз:] Акрын, нинди саксыз сез! Сөйләшмәгез, дим!* М.Җәлил. *Саксыз куян баласы*

2) Саклыкны белмичә яки онытылып эшләнә, шуны белдерә, күрсәтә торган (хәрәкәт, эш-хәл һ.б.ш. тур.). *Өстәвенә бу саксыз хәрәкәт бөялеп торган бозларның тынычлыгын алды.* Г.Ахунов. *Таймасның нәүмиз күңелен, сагыш-хәсрәтләрен, сагынуларын ул яхшы аңлый, ә табигый нәзакәтлелеге аңа, саксыз сүз ычкындырып, малайны рәнҗетмәскә куша иде.* А.Тимергалин

3) Милектән бәрәкәтсез файдаланучы, сакчыл түгел. *Саксыз хуҗа*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Саклыкны белмичә яки онытылып, җиңел карап. *Шулай да, юлбарыс белән очрашканда шаярырга, саксыз кыланырга ярамаганлыгын аңлап, ау агасы аның янына тагын өч-дүрт таза ирне куйды.* Н.Фәттах. *--- ничәмә ничә кешенең саксыз эш итүе аркасында, формалинлы орлык ашап, сарыгы, казы-тавыгы үлде.* М.Мәһдиев. *Саксыз ычкындырылган сүзләр аркасында эш урыныгызда низаг килеп чыгу ихтимал.* Ватаным Татарстан

2) Әрәм-шәрәм итеп, туздырып. *Акчаны саксыз тоту*

3) Сакчысыз, каравылчысыз. *Баржаны саксыз тотмаслар.* Г.Ахунов. *– Артыңнан җап! – дип кычкырды карт. – Төнката чапма, җырт саксыз кала.* Н.Гыйматдинова

**САКСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Саксызлык күрсәтү, саксыз эш-хәрәкәт итү

2) Саксызга әйләнү, саксыз рәвештә эш итә башлау

**Саксызлана башлау** Саксызлык билгеләре күренү

**Саксызлана төшү** Тагын да бераз саксызлану

**Саксызланып йөрү** Озак вакыт саксызлану. *– Нигә ул [командир] ут астында болай саксызланып йөри? – диде блиндажда калган элемтәчеләрнең берсе.* Г.Әпсәләмов

**САКСЫЗЛЫК** *и.* Саксыз булу сыйфаты. *Шулай да саксызлык та җибәрде Гөлсем ханым.* С.Поварисов. *Саксызлык белән эләгә калсаң, син безне белмисең, без – сине. Надан мин, диген, аңгыра, диген.* Я.Зәнкиев. *Кечкенә генә саксызлык та авария китереп чыгарырга мөмкин.* Л.Шафикова

**СА́КУРА** *и. яп.* Япониядәге алсу чәчәкләр ата торган декоратив чия агачы. *Япониядә сакура быел гадәттәгедән 10 көнгә иртәрәк чәчәк аткан (сакура*

*чәчәк ату илдә чын яз җитүен аңлата).* Татарстан яшьләре. *Халык бәйрәмнәренең иң күркәмнәреннән берсе – сакура чиясенең чәчәк атуы бәйрәме.* Материклар һәм океаннар географиясе

**САКЧЫ** *и.* 1) Нәрсәнедер сакларга билгеләнеп, сакта торучы кеше, төркем һ.б. *Дөяләр җигелгән арбаны ян-яктан, арттан, алдан унлап-унбишләп сакчылар урап алганнар иде.* Н.Фәттах. *Шуның өстәвенә баржаның үзендәге сакчылар да бер дистәдән ким түгелдер.* Г.Ахунов. *Ишекнең ике ягында ике сакчы тора иде.* С.Поварисов

2) *спорт* Футбол, хоккей, баскетбол һ.б.ш. уеннарда үз командасының капкасын (боҗрасын һ.б.ш.) саклау йөкләнгән уенчы. *Бөтерчек кебек бөтерелә-бөтерелә, әллә нинди алдавыч хәрәкәтләр, баш әйләндергеч финтлар ясап, ярымсакчыларны узды, сакчыларны як-ягында калдырып, капкачы белән күзгә-күз чыкты да тупны нәкъ югары почмакка җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Уң як сакчы. Сул як сакчы*

3) *күч.* Нәрсәне дә булса яклаучы, саклаучы. *Әй, хорафат, искелекнең сакчысы! Туктыйсыңмы?* Һ.Такташ. *Минем фикерләремнең ачыкларының да, яшертеннәренең дә сакчысы ул [Баязит абый].* А.Гыйләҗев

**САКЧЫЛ** *с.* 1) Милектән бик сак файдаланучан. *[Мәрьям:] Син ай-һай сакчыл да соң. [Нури:] Өй җиткерәсем бар бит.* Ю.Әминов. *[Гөлсылу:] Мин саран түгел, мин сакчыл!* Р.Гаязетдин

2) Куркыныч булу мөмкинлеген исеннән чыгармаучы; игътибары бик көчле; сак

3) Кайгыртучан, игътибарлы, сак. *Экологиягә сакчыл караш*

**САКЧЫЛЛАНУ** *ф.* Сакчылга әйләнү; сакчыллык күрсәтү

**Сакчыллана төшү** Тагын да бераз сакчыллану

**Сакчылланып китү** Соңгы вакытта сакчыллану

**САКЧЫЛЛЫК** *и.* Сакчыл булу. *Алар хәзер ашауда булсын, кием-салымда булсын аерата сакчыллык күрсәтә башладылар.* А.Расих. *Сәламгали абзыйның иң нечкә җире – сакчыллык.* И.Сафин. *Монда бернинди тылсым юк, ул – фәкать энергия куллануда сакчыллык чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсе.* Ватаным Татарстан

**САКЧЫЛЫ** *с.* Кемдер тарафыннан саклана торган. *Хәдичә, сакчылы капка янындагы будкага кереп, эчкә [губернатор канцеляриясенә] узарга рөхсәт алды.* А.Расих. *Әлеге банда өч ел буена нәкъ шушындый «намуслы» угрыларны өркетү өчен генә куелган сакчылы кибетләрне бернинди тоткарлыксыз талап килгән дә инде.* Безнең гәҗит

**САКЧЫЛЫК** *җый. и.* 1) Сакчылар, сакта торучылар. *Батальондагы күтәрелеш иң элек склад сакчылыгын юк итү һәм коралга ташланудан башланачак.* Ш.Маннур

2) Сакчы хезмәте, вазифалары. *Хәтта бу тынлыкка җиңелгәннәр, Йоклаганнар каравылчылар да. Оеп, шунда утырып калганнар, Сакчылыкны онытkan алар.* М.Гафури

3) Саклана торган урын. *Тимерчыбык киртәсенең тышында, чама белән егерме биш метр киткәч, сакчылыкның икенче сызыгы башлана.* Г.Әпсәләмов

**САКЫЙ** *и. гар. иск.* Табында утыручыларга су яки исерткеч эчемлекләр салып бирүче кеше. *Уйла, сакый: күкрәп үскән бу чәчәкләр Бер атнадан сулачаклар, кибәчәкләр!* Х.Туфан. *Робагый кебек шигъри тулпарны Бөек Хәйям яр янына, яки сакый тарафына җилдерер өчен генә иярләмәгән, ул галәмне иңләр өчен, гарешкә ирешеп, илаһият белән гәпләшер өчен иярләгән.* Кызыл таң

**САЛ** *и.* Су белән агызып алып бару яки паром урынына файдалану өчен теркәп бәйләгән бүрәнәләр. *Быел көймә һәркемнең үзенә кирәк, шуңа күрә аңа да, Солтан белән икәүләп, барлыюклы бүрәнәдән, такта-токтадан сал әмәлләргә туры килде.* Г.Ахунов. *Агыйделдә ике сал: Берсе каен, берсе тал. Сагынганда үкенерсең, Әйтер сүзең әйтеп кал.* С.Әхмәтҗанова

**САЛА** *и. рус* Зур авыл, карья; авыл җире. *Болар – сала мужигының ел саен кабатлана торган төп эшләре.* Г.Ахунов. *Имеш, салаларга ургылып цивилизация керә.* Н.Гыйматдинова. *Кала үсә, кала байый, Саладан ала-ала...* Мөҗәһид

◊ **Сала кабартмасы** *кимс.* Авылдан чыккан кеше, авыл кешесе. *Сельхоздан килеп йөрүче юк иде сыман. Бу сала кабартмасы тилергәнме әллә?* А.Гыйләҗев. *Казан егете шул, Идрис сыман сала кабартмасы түгел...* А.Гыйләҗев. **Сала саламы** «Культурасыз, югары әдәп нормаларын белмәүче кеше» мәгънәсендә. *Ә ул, сала саламы, сыер сыйрак, каршы килеп чемоданын да алмый, кара инде моны!* Ф.Яхин

**САЛАБАШ** *и. диал.* Юкә кабыгы

◊ **Салабаш төшерү** *диал.* Юкә кабыгын суга салып тотып, мунчала чыгару; юкә төшерү. *Быел җәй авыл хуҗалыгы эшләрен эшләү өстенә, абзый һәм башка берничә кеше белән Инҗәр буена, нииндидер бер рус баеның җиренә, салабаш төшерергә бардык.* М.Гафури

**САЛАВАТ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Мөхәммәд пәйгамбәргә хөрмәт белдерү өчен укыла торган дога. *[Ат карагы:] Капка астын казып, йортка керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен этка ташлыйсың.* К.Тинчурин. *Пәйгамбәргә салават әйтү*

2) Мактап-хуплап яки хәерле юл, уңыш теләп укыла торган дога. *Кари әфәнде үзе аллы-гөлле тавыш белән кычкырып, салават көйләп тора.* Ф.Әмирхан. *Этнең өреп торуы береңә дә салават түгел...* Ш.Камал

**2.** *хәб. функ. сөйл.* Юнәлеш килешендәге сүздән соң: «Хәерле булсын, аның хакында сүз озайтуның кирәге юк» мәгънәсендә әйтелә (үткән эш-хәл тур.). *Үткән эшкә салават.* Мәкаль. *[Файдалы бер очрашу аркасында лекциясен хәзерлексез үткәргән укытучы:] Ярар, бер лекциягә салават. Хәерле каза булсын.* М.Госманов

◊ **Салават әйтү** Мактап-хуплап яки хәерле юл, уңыш теләп дога уку. *Аталар, озата барып, әйтеп йөри салават, Барча халык дога кыла, кайтсыннар, дип, сәламәт.* Бәет. *Сөйләгәндә, гади сүз сөйләмәгәнене белгәнгә, сүз араларында салаватлар әйтә, «Разый Аллаһе ганһе, рәхмәтуллаһи галәйһи»-ләр берлә бизәкли иде.* Г.Исхакый

**САЛАВА́Т КҮПЕРЕ** *и.* Кояш нурларының су (яңгыр, томан һ.б.ш.) тамчылары аша үтеп сынуы нәтиҗәсендә

барлыкка килә торган төрле төсле дуга рәвешендәге оптик күренеш, җәйгор. *Офыкларны каплап балкып киткән Салават күпере кебек бу гомер. Көннәреңне серле итәм дисәң, Гашыйк бул син миңа тагын бер.* Д.Булгакова. *Салават күпере төсләре Кузгата, уйната хисләрне.* М.Миншин. *Салават күпере кебек Күңелем хыяллары.* Ә.Кәшфуллин

**САЛА́ГА** *и. рус* Яшь, тәҗрибәсез, булдыксыз кеше; маңка. *Нигә әле мондый хөрмәт бу салагага, янәсе.* Р.Зәйдулла. *Сәмикъ малае белән өч смена суктырдык. Салага бит әле ул, мәктәп баласы.* Н.Гыйматдинова

**САЛА́КА** *и. фин. зоол.* Сельдьчәләр семьялыгыннан күпләп аулана торган вак балык. *«Майдагы шпрот» консервларын әзерләү өчен, килька яки салака балыклары кулланыла.* Ватаным Татарстан

**САЛАМ** *и.* **1.** Ашлык сабагы. *Көне буе эшләсә, салам өзәр рәте дә калмый кешенең.* С.Поварисов. *Аларга хәзер, кем әйтмешли, салам да бүрәнә булып күренә.* А.Расих. *Безнең авылның урман юлындагы басуда үскән бер генә учма яшел борчак җибәрә алмыйсыңмы, саламы-билчәне белән.* М.Мәһдиев // *җый.* Сукканнан соң кала торган шундый сабаклар. *Саламда торган ат саламга барырга гына ярый.* Мәкаль. *Әле яңа унҗиделәрен тутырган кырыкка якын малай, арыш саламы түшәлгән суык вагонның почмакларына каз бәпкәләредәй төркем-төркем җыелып, укмашып-укмашып утырдылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Киң басуда салам эскертләре каракучкылланып күренә.* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ.* Шул ашлык сабагыннан яки шуны катнаштырып эшләнгән. *Җәйнең иң эссе көннәре башланып, салам түбәләр, читән чыбыгыннан үрелгән абзар-куралар көйрәп китәрлек хәлгә җитеп әлсерәп утырганда, Күктау авылында янгын чыкты.* А.Гыйләҗев. *Камыш чыпта өстендә аякларын бөкләп утырган, башына салам эшләпә, өстенә керләнеп беткән ефәк халат кигән хөкемче зур башлы, зур йодрыклы һәм куркыныч күз карашлы бер кеше иде.* Н.Фәттах

◊ **Саламга сөяү** Алдау. *Шуларны искә алып, --- иптәшләрегезне саламга сөяп йөрегез дә, инде аларның баш шәрифләрендә икеле-микеле уй кузгалмас өчен, «атудан» шып туктагыз.* Г.Мөхәммәтшин. **Салам кыстыру** *к.* **салпы якка салам кыстыру**. *Ярар, ярар, салам кыстырмагыз, зинһар.* А.Шамов. *Шунлыктан сөекле бабаларының бу ягына да салам кыстырулары гаҗәп түгел.* Г.Мөхәммәтшин. **Салам сыйрак** *гади с.* Нечкә озын ботлы яки гомумән физик яктан йомшак кеше турында. *Минбеләмлек дәгъвасын кыйлган була, салам сыйрак!* Г.Тукай. *[Саҗидә:] И бозау бәбәк, салам сыйрак, тавык баш! Сөйләшкән була бит тагын.* К.Тинчурин. *Еллар буе бер мәртәбә дә ял итмәгән колхозчы хатынның фидакярлеген, тиңдәшсез батырлыгын иртәнге гимнастика вакытында биш мәртәбә бил бөккәч тә уф-уф дип камыш көрсигә барып утыра торган салам сыйраклар язармы?!* А.Гыйләҗев

**САЛАМА́НДРА** *и. фар. зоол.* Койрыклы җир-су хайваннары отрядына караган кәлтәгә охшаш хайван; сәмәндәр

**САЛАМАТ** *и. диал.* Камчы; чыбыркы. *Аны Нурат үреп биргән саламат кызыктырды булса кирәк. Авырганда, атасының саламат алып кайтасын кабат-кабат исенә төшереп саташа иде бала.* Т.Нәбиуллин

**САЛАМЛЫ** *с.* 1) Салам салынган яки тутырылган (капчык һ.б. тур.). *Чаршауның астына саламлы капчыклар беркетелә.* Шәһри Казан // Салам катыш булган (мал азыгы, тирес һ.б. тур.). *Теге саламлы тизәк лычкылдарлык дәрәҗәдә су ташыгач, ике баланың тиздән югары сызганасың да шуны басарга, ягъни изәргә тотынасың.* Ватаным Татарстан

2) Саламы күп булган, саламга уңган (ашлык тур.)

**САЛАМЛЫК** *и.* Салам саклый торган урын. *Әхмәт алып кайтты да, Саламлыкка ятты да, Чукмар кадәр тәмәкене Авызына капты да, Бер-ике кат тартып алып, Кире җиргә ташлады...* Һ.Такташ

**САЛАМТОРХАН** *и.* 1) Халык әкиятенең мәшһүр каһарманы. *«Җефет» тапты үзенә тиң күреп ул, Булып чыкты Саламторхан кебек ул.* Котб. *Тик җүләр балык шикелле торам. Читтән караган кеше Саламторханның патша сарае янындагы торуын искә төшергәндер.* Г.Тукай. *Таш кысып май чыгаручы Камыр батыр да, корчаңгы аты белән таз малай да, Саламторхан да авылдашларың кебек үк таныш кешеләрең булып китә.* Г.Бәширов

2) *күч.* Һавалы, масаеп йөрүче булдыксыз кеше. *Чөнки беренче курсларда аны әнә шул икенче төркем вәкилләре, әтиләренең фамилиясе яки акчасы белән масаеп йөрүче саламторханнар урап ала торган иде.* А.Гыйләҗев. *Тора-торгач ул үзеннән-үзе көлә башлады: – Их син, мыеклы сабый, саламторхан!* Г.Бәширов. *Теге саламторхан слесарь белән бергә икесенең берьюлы кабинаның ике канатына кувалда белән кундыруы булды – пар торбаларыниләре, коммуникацияләре-ниләре белән бергә өч кабина идәнгә төшеп гөрселдәде.* А.Хәлим

**САЛАМЧЫ** *и.* Ашлык сукканда, салам селкү, саламны ташу, өю кебек эшләрдә эшләүче. *[Комбайнчы] штурвалны әйләндерә, шул ук вакытта я тракторчыга, я саламчы кызларга бәрәр боерык биреп ала.* Г.Гобәй. *Саламчылар салам чөйделәр.* Ш.Маннур

**САЛАТ** I *и. рус* Сыра, квас, исерткеч эчемлекләр, чүпрә ясауда кулланыла торган үрдереп тартылган ашлык оны. *Вакытында колмагын да, салатын да таба алмаганга, без бу ел күчмәләп маташмаган идек, гаеп итмәгез инде, егетләр.* М.Гали. *Шунда ук тезелеп киткән салат заводларыннан бераз татлы да, азрак төче дә, шул ук вакытта кызарып пешкән ипи катысы исен дә хәтерләтә торган салат исе аңкып тора.* Г.Бәширов

**САЛАТ** II *и. ит.* 1) Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан яфрагы чи килеш ашамлык итеп файдаланыла торган яшелчә үсемлек. *Матур, тигез рәт булып тезелеп киткән түтәлләргә суган, кызыл торма, салат, укроп кебек яшелчә-үләннәр чәчеп чыкты.*

Г.Гыйльманов. *Салат яфрагы. Салат төсендәге*

2) Пешкән яисә чи яшелчәдән генә яки аның янына ит һ.б. нәрсәләр турап, нинди дә булса тәмләткеч салып әзерләгән салкын азык. *Табын мул иде: көне буе алар кышкы салат, «шуба», винегрет әзерләделәр, токмачлы-итле аш пешерделәр.* Р.Зәйдулла. – *Бер үзгәреш тә юк дип әйтерлек, Әнвәр Хөснуллович, – дип сүз башлый прораб һәм, салат тәлинкәседәй пеләшен капларга тырышып, коелмыйча калган бишалты бөртек чәчен кулы белән сыпырып куя.* Ә.Сафиуллин

**САЛАТЧЫ** *и.* Салат (I) әзерләү өчен ашлык үрдерү белән шөгыльләнүче эшче. *Бик озын буйлысы – чандыры, Нәбиулла атлысы – Петсольдның сыра заводыннан, салатчы.* А.Расих

**САЛДАТ** *и. нем. сөйл. к.* **солдат**. *Салдат улымның хатын укып бирмәссеңме икән, энем?* Г.Бәширов

**САЛДА́У** *и.* Зур балыкларны чәнчеп тота торган берничә япьле корал, чәнечке. *Салдау белән балык тоту*

**САЛДЫРУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **салу** I **1.** (*1–4, 6–31, 33–40, 42–54, 56–62 мәгъ.*). *Элекке теләнче Мохтар хәзер инде Мохтар әфәнде Хәмитов булып, имам булган Хисаметдинга үз акчасына мәдрәсә салдырды вә мәдрәсә шәкертләренә кесәсеннән тереклек итәр өчен акча билгеләде.* М.Акъегет. *Най көчле куллары белән тиеннең тиресен салдырды һәм ботарлап ташлады.* Т.Нәбиуллин. *Әллә ни арада гына бер чыбыкның кабыгын көпшә итеп салдырды да сыбызгы ясап бирде.* М.Мәһдиев

2) *күч. сөйл.* Эре-эре атлау турында. *Пар ат матур гына салдырып китте.* Ш.Әхмәдиев

**Салдырып җибәрү** Озакка сузмыйча салдыру. *Немецлардан кала Этколда руслар да зур тегермәннәр салдыра, шулай ук татар бае Үтәмишевләр дә немецларныкыдай биш катлы тегермән салдырып җибәрәләр.* Ә.Еники

**Салдырып тору** Салдыру процессында булу

**Салдырып яту** Хәзер салдыру белән мәшгуль булу. *Аның каравы, Хәмитнең кече улы шушында ук, капканың уң ягында гына, зур таза йорт салдырып ята.* Ә.Еники

**САЛДЫРУ** II *ф. йөкл. юн. к.* **салу** II (*1 мәгъ.*) // Кемнең дә булса өс яки аяк киемнәрен, башка әйберләрен чишендереп, ычкындырып яки бөтәнчә алу. *Кичә Казанда ундүрт фатир талаганнар, утыз ике бүрек салдырганнар, өч кешене үтергәннәр, ике кызны көчләгәннәр.* Р.Зәйдулла // Хайванның йөгән, тышау, камыт кебек нәрсәсен ычкындыру, чишү, кире алу. *Серен белмәгән атның авызлыгын салдырма.* Мәкаль. *Хәлфә кыска буйлы иде, аңар Солтан алдында, озын торыклы байталның камыт-ыңгырчагын салдыру өчен, атны тарантас янына китерергә туры килде.* Г.Ахунов. *Күк айгырның да хәлен аңлап булса кирәк, бер көнне ул аны ишегалды белән янәшә бакчага йөгәнен салдырып кертеп җибәрде.* Ә.Еники

**САЛИДУЛ** *и. лат. сөйл. к.* **солидол**. *Әйдәгез, барып карыйк әле, иртән [арбаның] тәгәрмәчләрен салидул белән майлап ята иде [Хәмит].* З.Зәйнуллин. *Минем карт салидул белән генә майлый күрәкне.* Идел

**САЛКЫН** *с.* **1.** 1) Түбән температуралы; суык. *Төнге салкын зәмһәрирдән Туңды күңлем, алтыным!* Һ.Такташ. *Сәҗидә, син салкын суга чылаткан тастымал белән тирләрен сөртеп ал, алмашка тагын шундый бер сөлге әзерлә, кирәк булачак әле*… Г.Галиева. *Шыксыз күзләр, салкын кышлар узар, Янәшәңдә, бәгърем, калырмын*… Д.Гыйсметдин

2) Җылылык бүлеп чыгармый яки җылылык чыганагы була алмый, яисә җылылыгы сизелми торган (төрле җисемнәр, нурлар тур.). *Болыт араларында салкын йолдызлар җемелди.* И.Гази. *Салкын планета. Салкын нурланыш*

3) Кайнарлыгы яки җылылыгы беткән, суынган (аш-су тур.). *Мәктәптән ат җигеп кайтты, тарантаска мылтыклар, патроннар төяде, алар янына салкын ит, тозлы кыяр, гөмбә, пәрәмәчләр тутырды.* А.Гыйләҗев. *[Нуриман абзый балаларына] Чәйнектә көндездән калган салкын чәйне эчертеп, йокларга яткызды.* Г.Ахунов. *Чәй кайнатып маташмады [хатын], кичәгесен генә берничә мәртәбә уртлап куйды, салкын тары боткасы капкалады.* Р.Зәйдулла

4) Җылытмыйча гына әзерләнә һәм табынга кайнар килеш куелмый торган (ашамлык тур.). *Артык мул булмаса да, монда ашларның салкыны да, кайнары да бар.* А.Тимергалин. *Эсседә майлы, авыр ризыклар ашамагыз, яшелчә, җиләк-җимеш, окрошка кебек салкын ризыкларга өстенлек бирергә кирәк.* Сабантуй

5) *махс.* Кыздырмыйча яки түбән температурада эшләнә торган (эшкәртү һ.б.ш. тур.). *Сәгатьнең вак кына детальләрен эшләүдә дә бик зур машиналарның катнашы бар. Салкын штамповка бүлегенең бер почмагында идән белән түшәм арасын тутырган зур пресс --- бер үк төрле деталь эшләп чыгара.* М.Максуд

6) *күч.* Дәртсез, хиссез; кырыс, ягымсыз. *Мин сине яраттым. Кайнар беренче мәхәббәтем белән. Ә син миңа карата боздан да салкынрак булдың.* С.Поварисов

7) *күч.* Артык җитди, артык рәсми мөгамәләле. *Колактан кергән салкын сүз йөрәккә барып боз була.* Мәкаль. – *Син кем өчен яшисең, Туман каган?* – *диде Ана-кам, корыган агач шыгырдаган сыман дәртсез, салкын бер гамьсезлек белән.* Н.Фәттах. *Аңа караган саен, күңел өшегәндәй була, ул үзенең салкын гамьсезлеге белән үзенә тарта, гүя җанны үзенә суыра.* Р.Зәйдулла

8) *күч.* Гамьсез, җавапсыз (эшкә мөнәсәбәт, караш һ.б.ш. тур.). *Эшкә булган салкын карашны бетерү*

**2.** *и. мәгъ.* Салкынлык (*1 мәгъ.*); түбән температура, салкын һава. *Кем белә? Ах! Кем белә, Кайда сөеклем, алтыным Уздыра бу куркыныч Төннең зәһәрле салкынын?..* Һ.Такташ. *Тышкы ишектән чыгу белән, Туман каганның җылы битенә коры салкын килеп бәрелде.* Н.Фәттах. *Аяк астында төнгелеккә чираган юка бозлар чытыр-чытыр ватылып кала, төнге салкыннан ныгыган каты кар чабатаның биек агач күтәрмәсенә шакылдап бәрелә иде.* Г.Ахунов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Сүлпәнлек белән, җаваплылык тоймыйча. *Нургали абый, син аңа алай салкын карама инде.* Г.Галиева. *Элек анын заводларда, бригадаларда булырга тырышуын мактап телгә алган кайберәүләр хәзер «хезмәт тәртибен даими боза, үзенең төп вазифасына салкын карый, нәтиҗәдә, коллективны тарката, план өзеклеге тудыра» дип бәяләделәр.* А.Гыйләҗев

2) Хиссез, кырыс итеп. – *Җибәр! – диде хатын салкын итеп. – Миңа кычкырырга бер хакың да юк синең.* М.Кәбиров. *Салкын гына саубуллашып, Илдус белән Илдар затлы машиналары торган якка китеп бардылар.* Г.Гыйльманов

◊ **Салкын акыллы** Һәр адымын төптән уйлаучан. *Хатын-кызларны, бигрәк тә җитәкче эшләрдә эшләүче затларны, Нур Фатихович моңа кадәр коры, салкын акыллы, йорт җанлыксыз, берникадәр ялкау дип санап йөри иде.* А.Гыйләҗев. **Салкын алдыру** *к.* **салкын тидерү** *[Солдатларның] кайберләре мунча чыккан көйгә бозлы су эчеп, шунда ук салкын алдырдылар.* М.Гали. **Салкын алу** 1) *к.* **салкын тию**. *Ул бичаракай ничек өшеп, катып бетмәгән соң? Шунда салкын алса?* Ф.Әмирхан // Бик туңу. *Салкын алдым, калтырыйм.* Ш.Бабич. – *Салкын алмаса, күседән зыян булмас, – диде Габдрахман маклер.* Ф.Яхин; 2) Суыну (бүлмә, әйберләр тур.). **Салкын кан белән** Хисләргә бирелмичә, сабырлык һәм аек акыл белән. *Язган вакыттагы иҗат кайнарлыгы суына башлаганнан соң, салкын кан белән күз салганда, әсәр язгандагы кебек үк куандырмый башлый.* Г.Бәширов. **Салкын канлы** Хисләргә бирелмәүчән; аек фикерле һәм сабыр. *Салкын канлы бул, әмма каның салкын булмасын.* Ш.Галиев. *Вәлиәхмәтов кайнар һәм ялгыз диярлек, караклар тәҗрибәле һәм салкын канлы иделәр.* А.Гыйләҗев. *Ә энтузиастлар тыныч һәм салкын канлы булалармы соң?* А.Тимергалин. **Салкын канлылык** Үз-үзеңне тотышта, карашларда тынычлык һәм аек акыллылык. *Гадәттән тыш шартларда да салкын канлылыгын югалтмаган җырчыбыз гына тыныч иде.* А.Хәлим. *Инде мин салкын канлылык күрсәтеп, ымсындырып теңкәңә тиям!* Ш.Галиев. **Салкын корал** Чәнчү, сугу, кадау өчен хезмәт итә торган корал (кылыч, хәнҗәр, пычак, сөңге, кистән һ.б.ш.). *Капта өч кенә салкын корал ята иде.* Ф.Бәллүр. *Ә бервакыт, салкын корал белән янаган өчен, ир дигәнемне төрмәгә утырттылар, йолып алдым.* Татарстан яшьләре. **Салкын сугыш** СССР һәм аңа союздаш илләр белән АКШ һәм аңа союздаш илләр арасында Икенче Бөтендөнья сугышыннан алып 1990 елларга кадәр дәвам иткән глобаль геосәяси, хәрби, икътисади һәм идеологик киеренкелек. *Кемнәр соң сез «салкын сугыш»ка Су коючы Саламторханнар?!* Х.Туфан. **Салкын тидерү** Салкын тәэсиреннән чирләү. *Мин хәзергә бер генә киңәш бирә алам: салкын тидерүдән сакланырга кирәк.* Г.Ахунов. *Шыр тиле, бер кат күлмәктән генә чыгалармыни, салкын тидерсәң соң?* Ә.Еники. *Әллә Галимә түти салкын тидергәнме?* Н.Гыйматдинова. **Салкын тию** Өшү сәбәпле авырып китү турында. *Тиргә баткан атың, арып беткән, Сакла үзен, салкын тимәсен!..* Һ.Такташ. *Шул салкын тиюләрдән байтак органнарыгыз җәфаланган, сез бәбәй таба алмыйсыз, диде мөдир аңа [Диләгә].* А.Гыйләҗев. *Салкын тия күрмәсен тагын...* Р.Зәйдулла. **Салкын эләктерү** *к.* **салкын тидерү**. *Үзеңнең миңа кышның салмак чишмә суыдай агылып торган тыгыз һавасын да сулатасың килә, ә үзең, киемеңә кибетчедән кайтканда сеңгән суыкны теге өйдә эретеп бетермичә, минем янга да кермәдең, миңа салкын эләктерүдән шикләндең.* М.Хуҗин

**САЛКЫНАЙТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **салкынаю**. *Ләкин бу һәр әсәрне революция бозы белән салкынайту дигән сүз түгел.* С.Поварисов

2) Салкынаю (көн, һава тур.). *Татарстан синоптиклары, җомгада көн салкынайтачак, дип вәгъдә итә.* Ватаным Татарстан

3) *з-сыз.* Һаваның салкынаюы турында. *Әле кичә генә түбәләрдән тамчылар тама иде, ә менә хәзер кай арададыр салкынайтып та җибәргән.* М.Шабай. *Караңгы төшә башлады, кошлар тынды, салкынайтты.* А.Гыйләҗев

**Салкынайта бару** Торган саен тагын да салкынайту. *Ә төн һаман салкынайта бара.* В.Нуруллин

**Салкынайта башлау** Салкынайтырга тотыну. *Көннәр салкынайта башлады.* А.Алиш. *Көннәр салкынайта башласа, суыктан саклар өчен, түтәл кырыена каен ботаклары куеп чыгарга була.* Ватаным Татарстан. *Йөри торгач, көн кичкә авышты, салкынайта башлады.* Татарстан яшьләре

**Салкынайта төшү** Бераз салкынайту; тагын да ныграк салкынайту. *Салкынайта төшкәч, балалар табибларының эше бермә-бер арта*

**Салкынайтып алу** Кыска гына вакытка салкынайту. *Атна-ун көн салкынайтып алганнан соң, Татарстанга тагын чын җәй килде.* Татарстан яшьләре

**Салкынайтып җибәрү** Соңгы вакытта салкынайту. *Озакламый көннәр салкынайтып җибәрде.* Ф.Төхбәтуллин. --- *бүген яңадан салкынайтып җибәрде.* Ш.Алпар

**Салкынайтып кую** Кинәт салкынайту. *Көне дә көне бүген! 8 нче март дип тормады, салкынайтты да куйды.* Ялкын

**САЛКЫНАЮ** *ф.* 1) Салкынга әйләнү, температура түбәнәю. --- *һава шактый салкынайган иде.* Ш.Камал. *Каеннарның яфраклары саргая башлады, һава шактый сизелерлек салкынайды.* Г.Әпсәләмов. *Кичкә таба җир өсте акрынлап суына, һава да салкыная.* Башлангыч география курсы

2) *куч.* Ягымсызлану, артык кырыска әйләнү (холык һ.б.ш. тур.)

3) *куч.* Элекке эчкерсезлекне югалту (мөнәсәбәтләр тур.). *Ә менә әтисенең йөзе дә кырысланды, сүзләре дә салкынайды.* Ф.Садриев. *Аралары салкынайды, бер-берсеннән читләштеләр.* Ф.Дәүләтгәрәева. *Аның кызы башка милләт кешесенә кияүгә чыкты, Хәсән абый шуннан соң кызына салкынайды.* Р.Батулла

4) *куч.* Кызыксынмый башлау; кызыксынуны югалту, сүрелү. *Әдәбиятка салкынаю*

**Салкынаеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыйгадан соң салкынаю. *Без аны соңгы юлга озатканнан соң, тирә-як караңгыланып, бушап, салкынаеп калды кебек.* Безнең гәҗит

**Салкынаеп китү** Соңгы вакытта салкынаю. *Кояш күздән югала, шәһәр өсте караңгыланып, һава салкынаеп китә.* Ә.Еники. *Тәнем салкынаеп китте.* Н.Дәүли. *Ирләрнең киеменә сыланып кергән суыктан өй эче салкынаеп китте.* Н.Гыйматдинова

**Салкыная бару** Торган саен салкынаю. *Әмма комиссарның кызыл чырае салкынайганнан салкыная гына барды.* Ә.Дусайлы. *Ул апасының салкыная барган кулын тотып елады да елады.* Ватаным Татарстан

**Салкыная башлау** Салкынаюга табан үзгәрү. *Кулын күтәрергә һәм хәрәкәтләндерергә көче-тәкате калмыйча, аның кул-аяклары салкыная башлады.* З.Бигиев. – *Эрик, кадерлем! – дип, Рудольф хастаның салкыная башлаган кулларын алды.* Р.Батулла. *Урман эче салкыная башлады.* М.Мәһдиев

**Салкыная төшү** Бераз салкынаю; тагын да салкынаю. *Моңарчы йөзеннән китеп тормаган елмаюы да шиңде, салкыная төште кебек.* К.Тимбикова. *Көннәрнең салкыная төшүе Уралдан тизрәк борылырга мәҗбүр иткән.* Ватаным Татарстан

**САЛКЫНКАНЛЫЛАР** *и.* Кан җылылыгы чагыштырмача түбән һәм үзгәреп торган, салкын тәнле тереклек ияләре (мәс., балыклар, сөйрәлүчеләр). *Температура үзгәрешләренә салкынканлылар – тән температуралары даими булмаган хайваннар бәйле.* Биология. *Бакалар бит сез, салкынканлылар отрядыннан, салкын канлы бакалардан --- шигырь беркайчан да чыга алмый.* Р.Батулла

**САЛКЫНЛАНУ** *ф. к.* **салкынаю**

**Салкынлана башлау** *к.* **салкыная башлау**. *Көз башы: төннәр салкынлана башлаган иде.* Ш.Усманов

**Салкынланып җитү** Тәмам салкынлану. *Менә көтәр көн килеп йитә, көннәр салкынланып йитеп, чебеннәр, күбәләкләр үлеп бетә иде.* Г.Исхакый

**Салкынланып калу** *к.* **салкынаеп калу**

**САЛКЫНЛАШУ** *ф. диал. к.* **салкынаю**

**Салкынлаша бару** *к.* **салкыная бару**. *Бу һаман төпсезлеккә китә, түбән киткән саен диңгез салкынлаша бара.* Ш.Камал

**САЛКЫНЛЫК** *и.* 1) Салкын булу; суыклык. *Көннең чатлама салкынлыгы аны бик борчый иде.* А.Расих. *Күктән, куе салкынлыкны ертып, самолёт узды.* А.Гыйләҗев. *Бу чишмәнең суы үзенә бер төрле тәмле. Салкынлыгын кара син аның, шифалылыгын әйткән дә юк инде.* Г.Галиева

2) *күч.* Дәртсезлек, хиссезлек; гамьсезлек. *Бар нәрсәгә дә ниндидер бер салкынлык көчәйде аңарда.* Г.Минский. *Төс-кыяфәте мөлаем гына булса да, егетләр аңа ябышмыйлар, күзендәге салкынлык, йөзендәге җитдилекме аларны якын җибәрми иде.* Р.Зәйдулла

3) *күч.* Кырыслык

4) *күч.* Ошатмау, яратмауны, тискәре мөнәсәбәтне белдерә торган билге. *Әскәр аны-моны сиздермәсә дә, Кадриянең күңеле сизгер, ул ирендәге төшенкелекне, салкынлыкны сизеп, тирәнрәк уйлаган саен көеп, көнтаң атса сызып, борчылып ята иде.* А.Гыйләҗев. --- *Динисламның чыраендагы салкынлыкны күргәч, [атасының] тәне өшеп киткәндәй булды.* Г.Ахунов. *Халисәдәге салкынлык, битарафлык кинәт аны өшетеп җибәрде.* Р.Йосыпова

**САЛКЫНСУ** *с. диал. к.* **салкынча**. *[Музыка] авазлары кичке салкынсу һавада салмак кына йөзәләр иде.* И.Гази. *Кичтә һава салкынсурак була.* М.Укмасый

**САЛКЫНЧА** *с.* Бераз, җиңелчә салкын. *Булмә салкынчарак иде.* С.Поварисов. – *Әнкәй, минем бераз башым авыртып тора, сез чәй әзерләгәнче, келәттә, салкынча һавада, азрак ятып алырыем, – диде.* Г.Галиева. *Учы шуның салкынча шома түтәсенә килеп орынгач, ниндидер алҗыткыч рәхәтлек бөтен тәненә таралды.* Р.Зәйдулла

**САЛКЫНЧАЛАНУ** *ф.* Салкынчага әйләнү. *Кичен һава салкынчалану*

**Салкынчалана бару** Торган саен салкынчалану

**Салкынчаланып китү** Соңгы вакытта салкынчалану. *Көннәр салкынчаланып китте*

**Салкынчаланып кую** Кинәт салкынчалану

**САЛКЫНЧАЛЫК** *и.* Салкынча булу. *Шулай сүзсез генә бу көнне уздырып җибәргәннәрендә, кичке вакыт якынайганда, һавалар үзгәреп, шул үзгәргән һавалар бераз салкынчалык белән акыл шәрифләренә тәэсир итеп, иртәнге якта булган кимсенүләр онытылып, тагын да җайлашып бер урынга утырганнарында, алар янына икенче бер юлчы килеп чыккан.* Ф.Яхин

**САЛЛА́У** *ф. махс.* Сал итеп беркетү (бүрәнәләрне, такталарны һ.б.), берберсенә ныгыту, бәйләү. *Агач саллау*

**САЛЛЫ** *с.* **1.** 1) Авыр һәм нык; җиңел генә түгел. *Әхми куаклыгыннан саллы гына бер-ике карама колга кисеп кайтардылар.* А.Гыйләҗев. *Шул моңга ияреп, тамашачылар сәхнә ачылганын, саллы авыр пәрдәнең ике якка шуышып кереп җыелганын да сизми калдылар.* Г.Ахунов. *Секретарь ярты сәгатьтәнме, бер сәгатьтәнме эре генә дәү ишеккә ымлагач, ул каударланып шул ишеккә ташлана, үзенә кыюлык өстәргә теләгәндәй, кискен хәрәкәтләр белән авыр, саллы тоткага тотына.* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Төпле, нигезле; тәэсирле; үтемле, берәгәйле (сүз һ.б.ш. тур.). *Сүзләре бик саллы, дәлилләре каршы килерлек түгел иде шул [Зәйтүнәнең].* Г.Ахунов. *Югыйсә шигарь шәп бит! Үзе кыска, үзе саллы.* Р.Зәйдулла. – *Кешеләр әйбәт бездә, – дип, иң саллы дәлилне үлчәүгә китереп салды әкертен Гамил.* А.Тимергалин. *Саллы хезмәт. Саллы сәбәп. Саллы китап*

3) *күч.* Куәтле, ышанычлы, нык (хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Калку гәүдәсе, тыныч һәм саллы адымнары – кем икәнлеген, кара төстәге киеме, караңгыланып киткән хәсрәтле йөзе исә кайдан кайтып килгәнлеге хакында сөйлиләр сыман.* Ф.Яхин. *Төрле яклап йодрык яудыруның уңай ягы шул: беренчедән, аумыйсың, икенчедән, тыгызлык аркасында һөҗүмчеләр бер-беренә комачаулый, һәм саллы селтәнүле сугуларга җай чыкмый.* Татарстан яшьләре

4) *күч. сир.* Абруйлы, төпле, ышанычлы; көчле (кеше тур.). *Тик судья ягында да шактый саллы адәмнәр булып, алар юл куймаган.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *рәв. мәгъ.* Үтемле, тәэсир итәрлек, игътибарсыз калмаслык итеп. *Озын Вәлинең сүзе монда шактый ук саллы яңгырый икән, егетләр тынып калды.* Р.Зәйдулла

**САЛЛЫК** *с.* Сал бәйләү-ясауга китә торган яки салга ярарлык, шуңа җитәрлек. *Ике саллык бүрәнә. Саллык агачны елга буена чыгарып өю*

**САЛЛЫЛАНУ** *ф.* Саллыга әйләнү. *Ык суы нинди? Бер карасаң – аның төсе стакандагы су шикелле үтә күренүчән, кояш батканда – бакыр кебек кызгылт сары, кичләрен – саф көмеш. Көзгә таба ул куера, кургаштай саллылана.* М.Шабаев. *Клара апаның иҗаты көннән-көн саллыланып, көчәеп, халыкның ихтирамын казана.* Ватаным Татарстан

**САЛМА** *и.* 1) Токмач камырын, дүртпочмаклап кисеп яки вак кына кисәкләргә өзгәләп, шулпада пешереп алынган ашамлык; чумарның бер төре. *Туктан токмач кистермә, ачтан салма өздермә.* Мәкаль. *Салма салган ясмык ашы пешкән көн бәйрәмгә әйләнә!* А.Гыйләҗев

2) Шундый камыр салып пешерелә торган аш

◊ **Салма савыты** *гади* Авыз турында. *Фазлый, бирешмә, чәйдәш, салма савытына кундыр!* Т.Гыйззәт. *Бик ачуны китерсәләр, мәми авызларның салма савытларына да менеп төшәргә бик кыйбат алмабыз.* Г.Камал

**САЛМАГАЮ** *ф. к.* **салмаклану**. *Аның әсәрләре тирәнәя, салмагая, әмма хисләре көчәя генә, фәлсәфи уйланулары ешая гына, юморы үткенләнә генә бара.* Р.Миңнуллин

**Салмагая бару** *к.* **салмаклана бару**

**Салмагая төшү** *к.* **салмаклана төшү**

**САЛМАК** *с.* **1.** 1) Чагыштырмача әкрен, тигез һәм бер көйгә генә дәвам итә торган. *Йөзләп кулак Салмак адым белән Узып китте зур бер урамнан...* Һ.Такташ. *Бу юлы инде аның фикер агышы салмак һәм төпле бер тәртиптә иде.* Г.Ахунов. *Бу юлы мин аска карадым һәм салмак тавыш белән, күзләремне йомып, үземнең догамны башладым.* Ф.Бәйрәмова

2) Бераз салынып тора торган, салынкы. *Күк йөзе авыр, салмак, караңгы иде.* Г.Ибраһимов. *Салмак болытлар*

3) Чагыштырмача бәләкәй, вак булса да, шактый авыр, җиңел түгел. *Биш кадаклы салмак гер чырк итеп ялтыр түбәгә кунып алды.* М.Галәү. *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булган.* Г.Бәширов

4) Басынкы, сабыр (кеше, аның холкы һ.б.ш. тур.). *[Нәбиулла] салмак кешеләргә хас булмаган җитезлек белән урыныннан торды, Нурдидәсен биленнән кочып, көчләп диярлек бүлмәсенә алып кереп китте.* А.Гыйләҗев. *Шушы салмак холыклы, яхшы күңелле хатын чыннан да теге бөтен илгә танылган башкисәрнең туганы микәнни?* Р.Вәлиев. *Кыяметдин инде кыргый малайдан авыр, салмак карашлы иргә әйләнгән иде.* Ф.Бәйрәмова

**2.** *рәв. мәгъ.* Тигез һәм акрын гына. *Ә ул тауның теге ягында, еш-еш атлап, салмак басып менеп бара...* А.Гыйләҗев. *Агачлар саргайган яфракларын салмак кына коялар.* Г.Галиева. *Агыйдел салмак ага, Аккош канатын кага. Аккош кебек назлы ярым Күңел салмас башкага.* Р.Вәлиева

**САЛМАКЛАНУ** *ф.* 1) Авыраю

2) Нәрсәнең дә булса хәрәкәте, темпы әкренәю; салмагаю. *Әллә кем булган бит әнә, күренеп тора: бармакларыннан, бармаклары салмакланган... тук хәрәкәтләнәләр.* Р.Зәйдулла. *Нәүбәте җиткәч, Галия, каушавын сиздермәскә тырышып, идән уртасына чыгып басты, гармун тавышының салмакланганын бермәл көтеп торды да --- нәзек, саф тавыш белән җыр башлады.* Ф.Әһлиуллина

3) Басынкылану, сабырга әйләнү (кеше яки аның холкы тур.). *Ул салмакланган, аның хәрәкәтләре акрын.* Р.Батулла

**Салмаклана бару** Торган саен салмаклану. *Әкренләп аның тавышы җылына, салмаклана бара.* Р.Вәлиев. *Әткәемнең кар түсенә кергән аксыл чәче, салмаклана барган хәрәкәтләре, уйчан йөзе...* Безнең гәҗит

**Салмаклана төшү** Тагын да бераз салмаклану. *Йөкчеләрнең һаман әле туктарга исәпләре юк иде. Аларның көйләре шактый озынайды, ритм салмаклана төште.* М.Юныс. *Арыш инде күкрәккә җиткән, агарып килә, башакларын бөгә башлаган, чайкалуы да инде салмаклана төшкән...* Идел

**САЛМАКЛЫК** *и.* Салмак булу; әкрен кыймылдаучыга хас сыйфат. *Василь бар салмаклыгы белән ишектән перронга барып төште.* И.Салахов. *Ләкин сөйләгәннәренең анда нинди тәэсир калдыруын ачык тойган полковник шәрык кешеләренә хас салмаклык белән ашыкмый, кабаланмый гына бер чынаяк чәй эчте, икене эчте, бары шуннан соң гына дәвам итте.* Р.Мирхәйдәров

**САЛМАЛЫ** *с.* Салма салып әзерләнгән. *Салмалы шулпа*

**САЛМЫШ** *с.* Бераз исергән, айнык түгел, исерткеч эчкән. *Салмыш башкорт кодаларны көйләп, чөйләп, сыйлап, тотып алып кереп автобуска тутыра бара.* З.Зәйнуллин. *Хәлимәнең салмыш Сабирны тыңларлык тәкате калмаган иде.* И.Хәйруллин

◊ **Салмыш баштан** *к.* **салган баштан**. *Ул, салмыш баштан, туган абыйсына бер хатынны ошатуы, аның белән якын мөнәсәбәткә керүе турында сөйләде.* Ш.Алпар. *Тегесе бу хакта салмыш баштан ычкындырган.* Г.Гыйльманов

**САЛОН** *и. ит.* 1) Сәнгать әйберләре, кул эшләнмәләре, эксклюзив товарлар күрсәтелә һәм сатыла торган зал яки кибет. *Лениногорскида күптән түгел генә сәнгать салоны ачылды.* Татарстан яшьләре

2) Гадәттә югары дәрәҗәле хезмәт күрсәтү оешмасы. *Ул гади генә гүзәллек салоны түгел.* Шәһри Казан. *Чәчтараш салоны. Элемтә салоны. Портьер салоны*

3) Транспорт чараларында: пассажирлар өчен көйләнгән бүлмә. *Алар өчәүләшеп, тагын дүрт-биш юлчы самолёт салонына кергәндә, пассажирлар төрлесе төрле кыяфәттә йоклый-*

*лар иде.* А.Гыйләҗев. *Табигый фәннәр укытучысы һаман уянмаган Акпушын үзенең итәгеннән күтәреп алды да машина ишеген ачып җибәрде. Йоклаганны уята, арганны шундук йоклата торган саф һава килеп керде салонга.* Җ.Юныс. *Вагон ишек төбендә өч кыз көлешә. Үзара пышылдашалар. Сүзләре бөтен салонга яңгырап тора.* Ә.Дусайлы

4) Күргәзмәләр оештырыла, товарлар күрсәтелә һәм сатыла торган махсус бүлмә яки бина. *Балачак хатирәләрен искә төшереп торган балалар йортында Минсәлим абыйның остаханәсе, музей салоны эшләп килә.* Ватаным Татарстан. *Мода салоны*

**САЛПАЮ** *ф.* Салпыга (*1 мәгъ.*) әйләнү; салыну, салынкылану. *Ак өрфия шәлләр бәйләп бәсләрдән, Ябынгансыз, утырасыз салпаеп.* С.Исмәгыйлева

**Салпаеп тору** Салпайган хәлдә булу

**Салпая төшү** Тагын бераз салпаю. *Кола атым суга төште, Колаклары салпая төште.* Табышмак

**САЛПЫ** *с.* 1) Салынкы (*1 мәгъ.*), салынып торган. *Койрыгы салпы, Ике колагы кайчы, Аны белмәгәннең сыртына – каеш камчы.* Табышмак. *Галәмәт олы койрыклы, салпы колаклы сары эт ияртеп, каравылчы хатын, корпустан корпуска йөреп, ишекләрне ачты.* А.Гыйләҗев

2) Хәлсезлекне сиздереп торган, басынкы, сүлпән (хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Алиш, талчыгып эштән кайтучының салпы адымнары белән, ашыкмый гына эчкә таба керә.* Ш.Маннур

3) *күч.* Төшенке (күңел, кәеф тур.). *Аның ни өчендер күңеле салпы иде.* Ш.Маннур. *Ел тәүлеге – унике ай, Бу гадәт гаҗәп түгел. Мондый сурәт – салпы гадәт, Тик безгә хаҗәт түгел. Ел тәүлеге – унике ай, Безгә түгел, салпыга. Җиде елны үтәр өчен, Җитә безгә алты да.* Х.Туфан

◊ **Салпы якка салам кыстыру** Кемне дә булса үзе алдында мактаган булу, үсендерү. *[Әхәт:] Кызларын ташламасын дип, әби-бабай кияүнең салпы ягына салам кыстырамы?* А.Гыйләҗев. *Хатын-кызларны, салпы якларына салам кыстыра-кыстыра, алдан үткәреп җибәрделәр дә үзләре озын чүмеч артыннан тиз генә мич арасына шудылар.* Г.Галиева. *Салпы якка салам да кыстырырга онытмады [әтисе]: «Син бит безнең ише каткан авыз түгел».* Р.Зәйдулла

**САЛПЫЛАНУ** *ф. к.* **салпаю**. *Телеграф чыбыгы салпылану*

**Салпылана төшү** Тагын бераз салпылану

**Салпыланып тору** Салпыланган хәлдә булу. – *Җебеңне бераз тарта төш, салпыланып тормасын, – ди әнисе.* Д.Каюмова

**САЛПЫЛЫК** *и.* Салпы булу. *Басынкылык, кәеф салпылыгы әкренләп югала бара, күңелдә җиңеллек уяна.* Ш.Маннур

**САЛПЫРАЮ** *ф. диал. к.* **сәлперәю**. *Менә әткәң әле дә исән, Гөлсем. Тик бөкрәйгән аның җилкәсе. Кырауларда шиңгән чәчәк кебек Салпырайган ике иңсәсе.* Н.Баян

**САЛУ** I *ф.* **1.** 1) Берәр әйберне нәрсәнең дә булса эченә төшереп, куеп, кыстырып, агызып, коеп һ.б.ш. рәвештә урнаштыру. *Кылычларын салып кынына, Китте дошман килгән юлына.* Х.Туфан. *Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә анннары, иелеп алып, чиләгенә сала.* Ә.Еники. *Әнә ул ап-ак чиләктән чүлмәкләргә җылы сөт сала.* Ф.Әһлиуллина. *Китап эченә өрәңге яфрагы салу. Самавырга күмер салу. Улакка су салу. Документларны папкага салу*

2) Гадәттә озынча яки яссы әйберләрне кая да булса яткырып, аударып яки таратып кую, урнаштыру. *Аның артыннан кыска итеп киселгән утын түмәренә чабылган балталарын аркаларына салган Нурулла, Фәрваз, Риҗал һәм Ләбип ияргән.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулай «кем батар икән?» дип көтеп торсам, иңбашына көрәген салып, ишегалдыннан әти чыгып килә.* Г.Бәширов. *Художник асфальт өстенә үзенең эскизларын таратып салды.* К.Тимбикова // Берәр нәрсәнең өстенә куеп, орындырып-тидереп тору (кулны, башны, аякны һ.б.ны). *Керәләр дә алар мине сырып ала, Берсе килеп иңнәремә кулын сала.* Һ.Такташ. *Ат караучы абзый моны аңлады күрәсең: сабыйларча саф бер елмаю белән елмаеп, әле бүген генә танышкан үсмер егетнең җилкәсенә исән кулын китереп салды.* Г.Ахунов. *Фәсхетдин абый башын мендәргә салды һәм, бик нык арыган кешедәй, татлы йокыга чумды.* Р.Сәлим // Ике якка салындырып, аркылы кую. *Нурислам малайны алдына аркылы салган да авылга җайдак чапкан.* А.Гыйләҗев. *Гәрәй, каеш чыбыркысын кулбашына салып, сукрана-сукрана, түбән очка атлады.* Ф.Хәбибуллин. *Күңелем сизенгән икән, Гамис та шунда иде. Фетр эшләпә кигән, яхшы костюмнан, плащын, бөкләп, беләгенә салган.* М.Галиев

3) Җәеп-таратып яки сузып кую, урнаштыру; түшәү. *Агыйделгә басма салдым, Каенын сайлап кына.* Җыр. *Карчыкны иплән кенә утырттылар, мендәрен, таяныр өчен, янтыгына салдылар.* Ә.Еники. *[Исхак] Мунча ташына мул итеп кычыткан сала, бөтнек сала, мәтрүшкә сала.* А.Гыйләҗев // Вакытлыча яки тиз генә җәю, әзерләү (йокы урынын). – *Бибиҗамал әбиегез ятып торсын, урын салып бирегез, – дип, Зариф егетләрне алып чыгып китте.* Г.Галиева

4) Күтәртү яки күтәрү (йөк һ.б.ш. нәрсәләрне). *Аның [Хәдичәнең] аркасына авыр капчык салганда, Нурмөхәммәтнең эчәк-бавырлары өзелеп төшкәндәй тоела.* С.Поварисов. *Кыйналудан, газаплаулардан үзен-үзе тота алмас хәлгә килгән Айдаровны ике партизан җилкәләренә салып алып чыктылар.* Г.Ахунов. *Үләнле капчыкларны атлар сыртына Мирхәсән күтәреп салды.* М.Хуҗин // Төяү (йөкне). *Салам төяучеләр безгә юри күп салалар иде.* Г.Ибраһимов. – *Менә миңа карагыз! – дип мактана паровоз. – Туксан тугыз вагоным бар, Меңәр пот йөк салабыз.* Б.Рәхмәт

5) Гәүдә авырлыгын кайсы да булса әгъзага аудару. *Күтәрә башлауга, бөтен авырлыгын салып, Җәләй кешенең уң беләгенә ята һәм күтәреп алырга ирек бирми икән.* Н.Яһудин. *Чаңгыга баскач, хәрәкәт җиңеләйгәндәй булды. Таякларга авырлыкны саласың да чаңгыларны гына шудырасың.*

Ә.Маликов. *Яралы аяклары тыңламый, таякка бөтен гәүдәсе авырлыгын салып, әле бер, әле икенче аягын өстерәп диярлек йөри иде, мәрхүм.* Кызыл таң

6) Нәрсәне дә булса кимичә, өскә, иңгә ябу. *Өстәл янына утырган кеше аркасына мехлы пальто салган һәм үзе туңа торган кыяфәттә калтыравык тавыш белән ашыгып-ашыгып сөйли һәм дә тәрәзә төбендәге шешәләргә кулы белән күрсәтеп куя.* Ш.Камал. *Ул, әйбәт шәлен иңенә салып, кызлар кебек җиңел адымнар белән, югары очтан түбән очка ике тапкыр урап кайтты...* А.Гыйләҗев. *Яше белән дә, акылы белән дә Солтаннан өлкәнрәк булган Имам Каһарманов, җилкәсенә шинелен салган көйгә, аның янына килде.* Г.Ахунов. *Ул китүгә үк, хатын көзге каршына килеп басты, күлмәклекне туздырып иңнәренә салды, чәчләрен таратып җибәрде.* Р.Зәйдулла

7) Яткыру. *Салды саламга тол ана Сөеклеләрен, Чүпрәкләр белән аларның Япты өсләрен.* Х.Туфан. *Бала янә дә ныгытып елый башлагач, Габбаска китәргә ым кагып, баланы әнисе янына имезергә салдылар.* Г.Ахунов. *...Кызчыкны әле су исе дә китеп өлгермәгән талчыбык кәрзингә, ефәк юрган өстенә салдылар.* Ф.Әһлиуллина

8) Көрәштә: егу, җиңү. *Шулай да мин аңардан көрәшергә шактый ук өйрәнеп калдым һәм, бил ныгый төшкәч, үзем дә кайбер малайларны әйбәт кенә әйләндереп сала башладым.* Ә.Еники. *Быел Сабирҗанны сыртына салмасам, исемем Әхтәм булмасын, дип әйтә, ди.* Г.Галиева

9) Кемнедер нindидер бер максат белән кая да булса урнаштыру, кертү, бирү. *Калага илтеп укырга салабыз дисәләр, авылны ташлап китәр идеңме?* Г.Бәширов. *Без гаепсез идек ил каршында, Тик... төрмәгә безне салдылар.* Х.Туфан. *Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк», – диде.* Ә.Еники. *--- зимагур Шәяхмәт өчен «дапруска» тартканы, олыс өтерманендә зинданга салып йөрткәне өчен, ул аңар һәм, гомумән, Зартугай халкына бик ачулы иде.* Г.Ахунов

10) Ию, бөгү, салындыру, авыштыру (башны һ.б.). *Бу, бичара, куркуыннан күзләрен йомып, башын алга салып торды.* Ф.Әмирхан. *Мин үзем дә башны аска салдым, Нишләрмен, дип хәзер эчемнән.* Һ.Такташ // Төшерү, салындыру, аска юнәлтү (борынны һ.б.). *Борыныңны җиргә салуың кайгы галәмәтедер.* М.Акъегет. *Сөйлә әле син дә берәр нәрсә, Әллә нәрсә борның салгансың.* Һ.Такташ // Салындыру (керфекне, канатны һ.б.ш.). *Биленнән дә узып киткән калын толымнарының берсен күкрәк ягына салды.* Г.Галиева

11) Атлау, басу (аякны). *Үзе ул кечкенә буйлы, вак-вак кына атлап, кызу гына тыраклый, ә хатыны озын-таза, аякларын салмак кына эре-эре итеп сала.* Ә.Еники // *сөйл.* Ясау (гадәттә эре адымны). *Мөэзкир адымнарын эрерәк сала башлады.* А.Гыйләҗев // Ясау, йөртү (колачны, киң колач белән йөзгәндә – кулны). *Колач салыр идең, тез төпкә тия, басар идең, оят җирең елтырый...* А.Гыйләҗев. *Кереп карыйсы иде бит [күлгә], теге еллардагы кебек, колач салып, бер иңлисе иде бит!* Ә.Еники // Ишү (ишкәкне). *Өч пар ишкәкне алты кеше бер уңайга күтәреп сала башлагач, ул [көймә] килешсез кара бер җанвар кебек, дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп китте.* Ш.Камал. *Көймә, мәһабәт бер зифалык белән мачтасын авыштырып, дуга ясап борылды да ярга таба шуды һәм, ике-өч тапкыр ишкәк салуга, борыны белән ярга килеп терәлде.* А.Тимергалин

12) Аралаштыру-катнаштыру өчен, нәрсәне дә булса икенче бер әйбергә кушу. *Карчык, бик зур эш берлән мәшгуль кеби, чәй эчүен дәвам итте. Картка каршы бер сүз дәшмәенчә, кәҗә сөте алып кереп, чәенә салып эчә башлады.* Г.Исхакый. *Аяклары, сазлы җир булганлыктан, баскан саен, чүпрә салган кебек кабарып, пычтырдап торган кызыл балчыкка бата, аларны көч-хәл белән суырып алырга туры килә.* Н.Көбәш. *[Килене:] Мин ашка бәрәңгене салдым инде.* А.Әхмәт. *Хатыны чәй янына йомырка тәбәсе куырып китергән иде, тоз салырга онытkan булып чыкты.* И.Гази

13) Дәвалау яки дәвалану максаты белән дару кабул итү яки шприц кебек инструмент ярдәмендә тәнгә кертү. *Башкалар [армиягә бармас өчен] аяккул бозалар, күзгә, колакка агу салалар.* Г.Ибраһимов. *Уколлар салып, тәмам хәлләндереп киткәннәр иде хатынны, карасам, яңадан теге нәмәстә [тычкан] тәгәрәп чыгып килә...* Р.Сәлим // Банка, сөлек кебек нәрсәне тәнгә махсус кую. *Шул яз көнендә, көннәр җылынып йиткәч кенә, тамырдан кан алалар, мөгез салалар.* Г.Исхакый. *Тамырлар белән дә дәваладылар, сөлек тә салдылар. Ләкин эти тазармады.* Г.Бәширов. *Авыр күтәреп эчләре төшкән хатын-кызларга чүлмәк салырга да мине йөртәләр.* Г.Галиева

14) Яраланган, имгәнгән һ.б.ш. урынны саклау өчен, бинт, гипс кебек нәрсәләрне җайлап беркетү, кую. *Укуларың гел укол ясау белән шин салудан гына тормый бит, акыллым!* Р.Гаязетдин. *Ул, мотоциклдан егылып, аягын имгәткән иде, гипс салганнар.* Н.Көбәш. *Аңлавымча, яраны юган, тирене пластырь белән тарттырган да өстенә бәйләвеч салган.* Ватаным Татарстан. *Шок хәлендә калган егеткә «ашыгыч ярдәм» хезмәткәрләре авыртуны баса торган дару биреп, жгут салып, реанимациягә озатырга торганда, ул аягын эзләтә башлаган.* Безнең гәҗит

15) Тегеп, ябыштырып яки бүтәнчә беркетеп кую (ямауны, олтанны һ.б.ш.). *[Ярлы-ябагай] тузган-искергән чикмәненә кырык беренче ямавын сала...* Г.Ахунов. *[Рәйхана] Өр-яңа чабатага төп салам, дип калды.* З.Зәйнуллин. *Киез итекләргә олтан салып утыра идем, кулымдагы безне ачу белән идәнгә кададым да: – Баланың әтисе мин, – дидем.* Н.Гыйматдинова. *Күлмәккә кесә салу. Астар салу*

16) Ягу, сөртү, сылау, буяу һәм башкача йоктыру (пудра, буяу, бизәнү әйберләре кебек нәрсәләрне). *Ул эчке яулыгы өстеннән юка кәшемир шәльяулык бөркәнгән, аның күзләренә сөрмә тартырга, бит очларына иннек салырга да өлгергәннәр.* Г.Бәширов. *Шәүкәт Хәсәновичның грим сала торган*

*өстәлендәге кечкенә афишаларга игътибар итәм.* Ф.Әһлиуллина. *Шунысы кызык: БДИ аркасында агарган чәчләренә елына күпме буяу салалар икән?* Безнең гәҗит

17) Тамга, билге, бизәк-сыр кебек нәрсәләрне язып-сызып, уеп-чокып һ.б.ш. ысуллар белән кую, ясау, төшерү. *[Врачлар] Әскәрне «нестроевой» дигән тамга салып чыгарып җибәрделәр.* А.Гыйләҗев. *Ниһаять, туган авылы Нурлы Алан урамнарына үзе теләгәнчә бизәк сала, нур иңдерә алачак ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Ике көн элек кенә пилорам янында тәгәрәшеп яткан агачларны карап кайттылар, бурага дигәннәренә билге салып чыктылар...* Г.Гыйльманов

18) Резолюция, виза һ.б.ш. нәрсәләрне язу, бирү. *[Нина Михайловна:] Бөтен таләпләр үтәлсә, бер секунд тормыйм, имзамны салам!* А.Гыйләҗев. *Бераздан аңа ниндидер кәгазьләр өеме китерделәр, ул аларны укый, кирәкләренә резолюция салып алып куя, күпләрен ачып карый да калдыра, ачып карый да узып китә торды.* Ф.Яхин. *Шигырьләремә ниндидер виза салды да, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгән Саимә апа Ибраһимова янына җибәрде...* Р.Миңнуллин

19) Нәрсәгә дә булса дучар итү. *Вето салдым барлык мескенлеккә!* Зөлфәт. *Матбугат эшләре комитеты тарафыннан әлеге китапка арест салына.* З.Мансуров. *Кыскасы, Тукай үз иҗатында, Шүрәлесен авызлыклап, «шакшы сүзләр»гә табу салган, авыз пычратмаган.* А.Тимергалин. *Шул ук вакытта, статистика мәгълүматларына караганда, дару базарында файдалануга рөхсәт ителгән 20 препаратның 20 процентына 10 ел эчендә тыю салына.* Ватаным Татарстан

20) Башлау, ясау, яру (юлны, буразнаны һ.б.ш.ны). *Кәҗә сукмагын салып кайт әле, без дә шунда йөри башларбыз.* А.Гыйләҗев. *Чамаламый аз гына уңга каердыңмы, аста җәһәннәм чокыры, төштең, беттең... Һәм, тапканнар юл салыр урын.* С.Поварисов. *Бу елларны үрчегән пошилар, ахрысы, күлгә сукмак салганнар.* А.Тимергалин // Ясау, калдыру, барлыкка китерү (эзне, җәрәхәтне һ.б.ш.). *...Ә җыр тукталмас, Ул яра кебек Эз салып урнашыр күңелгә.* Х.Туфан. *Бодай басуында күлдәвекләр җыелган, пычрак ерганаклар күбекләнеп, әрле-бирле боргаланып, буразналардан эз салып, төрле якка агалар.* А.Гыйләҗев. *Ул [Зөһрә] инде, чыклы үлән өстенә беренче эз салып, чишмәгә барып кайтты, аннары Иделдән су ташыды...* Х.Сарьян

21) Кабызып җибәрү, төртү (утны). *Әлеге төш теләк очкынына ут салды.* С.Поварисов. *Учакка ут салгач, [Галимә] ялкын шәүләсенә текәлә дә хәрәкәтсез кала.* Н.Гыйматдинова

22) Нәрсәне дә булса һавага тарату, тирә-юньгә бөркү, бүлмәгә сеңдерү (төтенне, даруны һ.б.ш.ны). *Бәйләп алып кайтканнар да тондырганнар базга. Салганнар төтен.* Г.Бәширов. *Подвалга ыс салу* // Суны, эссесе, пары чыксын өчен, мунча ташына сибү. *Мунча дигәчтен дә, ул, әйткәнебезчә, су салып чыжлаган пар чыгара торган мунча түгел.* А.Хәлим // Эссене, парны ташка су сибеп чыгару, булдыру, ясау. *Улым, атаң мунчаны карап чыкты. Эссе салып, исләрен дә чыгарып бетерде, миллеген дә пешереп куйды.* Г.Галиева. *И ләүкәдә утыра җизнәң, и чабына, и чабына. Эссе сал да эссе сал, дие.* Г.Мөхәммәтшин

23) Аш-суны савытка бүлеп бирү. *– Кая, аш салып бир әле, – диде Галиулла, берни дә булмаган кебек.* К.Тимбикова. *– Юкса монда эчкечелеккә сабышуың да тиз, – дип аңлату кирәк тапты Эдлай һәм тәлинкәгә аш бүлеп салды.* А.Тимергалин. *Биктимер савытларга буы чыгып торган шурба салды.* Р.Зәйдулла // Малга, кош-кортка азыкны бирү, сибү. *Мин --- атның алдына бер-ике көлтә солы салдым.* Г.Бәширов. *Менә бүген өендә чыпчыкка салырлык та ризыгы юк икән.* С.Поварисов. *Азыкны ялгашларга бүлеп салгач, Мәгъфирүз үрдәкләрне ашата калды, Зөһрә белән Шамил кайтып киттеләр.* Х.Сарьян // Балага имезлек әзерләп бирү. *[Шәмсениса] Балага, ипи чәйнәп, имезлек салдырмады.* Г.Ахунов

24) Бит-кул юучыга суны агызып тору. *Шашлыкны ашап бетерүгә, тавышсыз картка ияреп яшь кенә бер кыз килеп керде, кул юарга кечкенә ләгән урнаштырды, комганнан су салып торды, дастарханны җыештырды, савыт-сабаны алыштырды, газетлар кертте.* Р.Мирхәйдәров

25) Туй бүләге, мәһәр кебек нәрсәне котлап табынга кую яки бирү. *Туй бүләге итеп салган күлмәклегемне дә яратмады, бизәге сары, минем саргаеп үлүемне телидер инде, дигән...* К.Тимбикова. *Бер туйда бүләк салуга килеп төртелгәч, кызмача әти кеше, күңеле киңәеп китепме, яшьләргә машина вәгъдә итеп ташлады.* Шәһри Казан

26) Отышлы өстәл уеннары уйнаганда, акчаны яки отышка дип билгеләнгән әйберне уенга кую. *[Кәрт уйнаганда] кайбер солдатлар күзенә берәр тиен генә салып уйнасалар да, сәгать эчендә җитмеш биш тиенне [барлык жалованьене] калдырып, читкә китеп утырдылар.* М.Гали. *Лотоны икешәр тиен салып уйнау*

27) Шобага кебек нәрсәләрне ясау, үтәү, тарту. *Автомат үзенең сыңар булса да үткер күзе белән шахмат тактасына текәлде. Жирәбә салдылар. Гроссмейстерга аклар эләкте.* А.Тимергалин. *Аулыбызда бер чибәр бар, Әйдә, салыйк шобага.* Җыр // Күрәзәлек итү максаты белән багу әсбапларын төрлечә таратып, аралаштырып тезү, урнаштыру. *Олуг падишаһ, безгә күрсәткән игътибарыгыз вә мәрхәмәтегез өчен тәшәккердән гаҗизмен, әмма ләкин әйтергә тиешмен ки, мин күрәзәче дә, фал салучы да түгелмен.* Ә.Еники. *Борчак салу. Нугыт салу. Комалак салу* // Берәр нәрсәне яки кешене шобага я багу предметы итү, жирәбәгә язып һ.б.ш. рәвештә объект итеп алу. *Егет сайлау уенында мине өч кат салганнар. Мин өчесендә дә Әсмага чыкканмын.* Г.Ибраһимов

28) *чыг. килеш. исемнән соң.* Чамалап карау, алдан билгеләү, бүлеп кую өчен хисаплау (керем-чыгымны һ.б.ш.). *Центнерын берәр сумнан гына салганда да биш машина ашламага йөз сум кирәк булу // юн. килеш. исемнән соң.* Алдан хисаплап, чамалап билгеләү, күңелдән бүлеп кую. *[Зәйнәпбану]*

*өстәмә итеп алачак бодаеннан йорттаниләр җиткерәсен, туйга ниләр әзерлисен исәпли иде: «Мунча мичenә салыйм бер өч пот, «үзенә» пальто тектерергә кирәк булыр кимендә биш пот. Аннары килеп, икебезгә киез итек бастырырга – тагын ике-өч пот...»* Г.Бәширов // Счёт белән исәпләү-санау. *Бар ул алар, күп ул бездә: Ният әйбәт булса да, Поэманы язганчы ук, Юл санына чут сала.* Х.Туфан. *Официант кечкенә счётында шалт-шолт салды да: «Сездән җәмгысе алтмыш тиен!» – диде...* Ә.Еники. --- *әллә ничә кат рәхмәтләр әйтеп, ишектән чыгып барганда, бөтен чут салу, кәгазь кыштырдау, сөйләшкән авазларны җиңеп, башлык хатынның көр авазы карчыкны куып тотты.* Р.Сәлим

29) Юнәлеш килешендәге үлчәм белдерә торган сүздән соң шул система бирәмлегенә күчерү; күчереп исәпләү. *Кошлар очып җитмәс ерак Себер ята иде арада. Чакрымнарга салсаң – ерак идегез, Йөрәкләргә якын эшче калалар.* Д.Фәтхи. *[Сугыштан кулсыз кайткан МТС директоры:] Бүгенге көндә ат көченә салсаң, шушы сыңар кулымда ничә мең ат көче бар!.. Я, ал элекке иң зур алпавытны. Аның ат куәтен кара... Минем янда кем ул?!* Н.Исәнбәт. *Центнерлы йөкне потка салып чамалау*

30) Берәр саклау урынына җыю, туплау яки саклыкка дип аерып калдыру (чәчү орлыгын, азык-төлекне һ.б.ш.ны). *Аннары баз уңаен такырайтып ук күрәргә дә кирәкми, кар тыгызлангач, баз өстенең ишек төбен генә казып төшәм дә, шул тирәдәге кар базга салырга җитә.* М.Хуҗин. *Хәтерлим әле, 7 нче сыйныфта базга бәрәңге салганда да, бер-ике бит китап укып ала идем.* Ватаным Татарстан

31) Сакларга тапшырып тору (кассага һ.б.ш. махсус җиргә). *Аның өстенә, биш-алты мең кассага салдым.* Г.Мөхәммәтшин. *Зур шәһәрләрдәге шикелле, монда акча салу, акча алу өчен банк та ачыла.* Ә.Еники // *махс.* Бурычка акча яки вакытлыча файдаланырга ни дә булса алу өчен, берәр әйберенне биреп калдыру, куеп тору. *Нигә эндәшмисез, әллә телегезне ломбардка салдыгызмы?* К.Тинчурин. --- *ул [Гәрәй], өендә хатыны, бала-чагасының хәле бик авырайгач, берәрсенә закладка салып булмасмы дигән исәп белән, актык казанын күтәреп чыккан иде.* Г.Ибраһимов. *Йортта мал-туар күп, иген-таруга байлык исә дә, акча калмаган, өстәвенә Җәләл йорт-җирне дә китәр алдыннан рәһенгә салган иде.* Г.Нигъмәти

32) Күңелгә, хәтергә алу, кабул итү (сүзне, киңәшне, кисәтүне һ.б.ш.ны). *Аны [хатны] үзендә саклый алмаячагын аңлап, юк иткәнче сүзен-сүзгә күңеленә салып калдырасы килеп, кат-кат укыды.* Г.Галиева. *Менә шушыларның барысын да күңелеңә салып куй!* М.Кәбиров. *Галстуксыз бу кеше белән әле тагын очрашулар булачагын карт күңеле белән сизә, шуңа ул аны хәтеренә салып кую өстенә аңларга да тырыша иде.* Р.Мирхәйдәров

33) Юкка чыгару, бозу максаты белән яки кадерсезләп берәр җиргә ташлау. *Ун пот биреп, мылтык алдык, Үрдәк атарга бардык. Ярамаган мылтык алып, Икмәкне суга салдык.* Һ.Такташ. *Күккә чөеп мактарлык булмаса да, җиргә салып таптарлык та түгел икән бит.* Н.Көбәш

34) Бирү, сарыф итү, чыгару (көч, сәләт, тырышлык, акчаны һ.б.ш.ны). *Әмма шуңа карамастан ул, йөрепсорашып һәм бик күп көч салып, менә дигән бакча үстерде.* Ә.Еники. *Әле без бит бирәдә ике ел эшләргә тиеш, һәм алай-болай гына да түгел, ә бөтен җегәрне, осталыкны салып.* Р.Фәизов. *[Хәерниса:] Өмәчеләрне сыйлау өчен дә, никадәр акчаны шайтан суына салырга кирәк.* Ю.Әминов. *Егет, уң учын ишек тактасына куеп, егәрен салып, инде көчәнеп этте.* М.Хуҗин

35) Юнәлтү, төбәү (уйны, зиһенне, ниятне һ.б.ш.). *Профессорга төбәлеп, аның әйткән бер сүзен тыңлап, күңел салып утыра башлый Нурия.* Г.Ахунов. *Хәер, Ярмөхәммәт андый төртмә сүзләргә игътибар салмый.* Р.Батулла. *Кыз аларның һәр сүзенә күңел салды, дикъкать бирде.* Ф.Яхин

36) Берәр төрле мәгънә, эчтәлек бирү (сүзгә, сөйләмгә, җырга һ.б.ш.га). *Маһирә бераз гына сабыр итеп, аның каршына үзе килде, һәр сүзенә тирән мәгънә салып, түземлек вә итагать белән көреште.* Г.Галиева. – *Һәркемнең үз сәгате инде... – дип өстәп куйды ул бераздан, сүзләренә мәгънә һәм шаярту төсмерләре салып.* Ф.Яхин. *Сандугач та үз сайравына фәлсәфи мәгънәләр салмый, аның максаты анык: ул былбыл кызын кавышырга чакыра...* Р.Зәйдулла

37) Ишеттерү, бирү (тавышны, авазны, өндәүне һ.б.ш.ны). *Үзе дә сизмәстән [Солтан]: – Һа-а-ай! – дип өн салды.* Г.Ахунов. – *Беренче авазын салырга вакыты җитә нәнинең дип, инде кичә үк уйлаганыем, – диде кендек әбисе, Газзәбануны күрү белән.* Г.Галиева // Тарату, ишеттерү-ирештерү (хәбәрне, сүзне, чакыруны һ.б.ш.ны). *Хәзер коллективта ирләр аз, миңа да сүз салып караучылар юк түгел.* А.Гыйләҗев. *Газзәбану килен ризалыгын бирүгә, миңа хәбәр салырсыз, никахыгызны, шәригать кушканча, үзем яңартырмын, Аллаһы боерса, диде.* Г.Галиева. *Алай гына да түгел, татарлар чакыру салса, шул маркетләр шундук магулларга каршы күтәрелә.* В.Имамов // Ясау, белдерү (ымны һ.б.ш.). *Мәүлиха апа да таптанып минем янда тора; күрәм, Кәримәнең дә миңа нидер әйтәсе килә: керфекләрен уйнатып миңа күз кыса, ым сала.* А.Гыйләҗев // Күңелдә туган ачу, гаҗәпләнү кебек хисләрне тавыш күтәреп белдерү. *Хатын дигәннәрең беркөнне Йорт эчендә гауга салдылар.* Һ.Такташ. *Оран сала йөрәк, сыкрый-сыкрый, Юл бирмәскә тели сагышка.* Х.Туфан. *Шушы хәлгә килешмичә ничек сөрән салмыйсың?* Р.Зәйдулла. – *Коебызда әллә мәче, әллә күсе үләксәсе, сукыр бәбәкләрем рәтләп шәйләмәде, харап! – дип, хатын һаман саен разбой сала.* Н.Гыйматдинова. *Бер карый, бер елмая, хәй-гәй сала аккош кеби.* З.Ярмәки

38) Почта һ.б.ш. элемтә хезмәте аша җибәрү. *Әнә сугыш бетәсе елны, немес-тән посылкалар кайткач, ничек булды? Аннан бит гел ефәк салдылар солдатлар.* М.Мәһдиев. *Үзе атна саен диярлек хат сала торды, әмма аның хатлары суга аккан кебек эзсез югалдылар.*

А.Гыйләҗев. *Хәтта минем исемнән акча, посылкалар салуын да монда кайткач кына белдем бит.* Г.Галиева

39) Берәр төрле рухи-психик халәт яки сыйфат тууга этәргеч бирү, сәбәпче булу. *Яфраксыз агач башларында, өй кыекларында һәм кайбер тәрәзәләрдә кояшның кызгылт шәүләләре чагылып, күңелләргә сагышлы уйлар сала.* Ш.Камал. *[Галимҗан] Студентлар күңеленә эстетик зәвык салды.* С.Поварисов. *Тугач та баланың күңеленә моң салмасаң, ул беркайчан да гамьле, гүзәллек яклы, миһербанлы зат булып формалашмый.* Н.Гыйматдинова // Коткы кебек нәрсәләрне тарату, чыгару, барлыкка китерү. *Элеккегә караганда да югарырак күтәрелә, йомшак җаннарга курку сала, икеле-микелеләрне нык өркетә бу горур баш.* С.Поварисов. *Шул ук вакытта, туганнан алып әлегә хәтле бер генә дә нужа күрмәгәннәр икән, дигән шомлы уй йөрәкләренә тынгысызлык сала.* З.Зәйнуллин. *Кешеләрнең күңеленә шом салып баруы рәхәт.* Р.Зәйдулла // Күңелсезлекне, бәхетсезлекне китерү, шуңа сәбәпче булу, шуңа дучар итү. *Дошманнары итеп Әскәр Моратов, асылда, гел бертөрле затларны – я алга чыгып, я артка төшеп үзенә нинди дә булса зыян салучыларны – --- исәпли иде.* А.Гыйләҗев. *Юньле карак үз авылына җәбер салмый, ди бит!* Г.Бәширов // Җәзаны бирү, шуңа хөкем итү. *Ул миңа нинди җәза салыр икән?* М.Фәйзи. *Себер җибәргәннәр элек, Җәза салып халыкка.* Татарстан яшьләре // Фикер, идея, план һ.б.ш. нәрсәне әйтү, бирү, күңелгә төшерү, хәтергә китерү. *Ярый әле, минем дә искә салдың.* Г.Минский. *Картинада теге аю үзенең Улларына сокланган кебек, Бер картыбыз йөри, бурычларны Искә салып, киңәшләр биреп...* Х.Туфан // Берәр төрле рухи халәткә яки хәлгә дучар итү, шуңа төшерү. *Салма хәсрәткә аны, Тәңрем, сузам кул иркеңә!* Һ.Такташ. *Бу табигый күренеш тә күпләрне хафага сала: телебез артык ярлылана, янәсе.* С.Поварисов. *Исән чагыңда да мине сары сагышларга салып яшәдең бит, җаным...* Г.Галиева. *Үзен борчуга салган сорауларга бер җавап та таба алмады ул.* А.Гыйләҗев

40) Төрле салым-җыемнарны түләргә дип билгеләү, шуңа дучар яки мәҗбүр итү. *Тук халыкны, сату-алу белән кайнашкан нэпманны совет бик каты китереп кысты, шатырдатып налог сала башлады.* Г.Ахунов. *Җиһангир агага әйтергә кирәк. Штраф салсын!* А.Тимергалин. *Моның өстенә император Маркиан Атилла ханга ясак салудан баш тарткан.* М.Хәбибуллин // Йөкләү; ясарга, эшләргә-үтәргә дучар яки мәҗбүр итү (чыгымны һ.б.ш.). *Чыгымны аның [мәрхүмнең] семьясы җилкәсенә салмыйча, бергәләп үз өсләренә алырга булдылар [кардәшләре].* С.Әдһәмова

41) Үз ирке-ихтыярына кую, калдыру, җибәрү. *Бераздан Хәсән мәхдүмне кайтарып, Хәсән әфәнде илә арабызда гакде никах идеп, аталарыбыз безне бер-беребезгә багладылар; фәкать, яшьлегебез сәбәпле, зөфафыбызны үз ихтыярыбызга салдылар, чөнки бән ул вакытта сигез яшемдә генә идем.* З.Һади. *Атланган кеше аны [чабып барган атны] хәзер ашыктырмый, үз ихтыярына салган.* Ш.Камал

42) Тәртипкә, җайга, нормаль хәлгә китерү, яраштыру. *Болай бармас бу сугыш, бер-бер рәткә салырлар, диешәбез.* А.Гыйләҗев. *– Юк-бар өчен әрләшмик әле, – дип, Илгизәр безнең менә-менә бозылырга тиеш мөнәсәбәтләребезне җайга сала.* Н.Гыйматдинова. *Ярый, мин әйтәм, хәзер юлга салабыз аны [төзекләндерү эшләрен].* М.Шабай

43) Көйгә, рифмага туры китерү, шуңа яраклаштыру (җырны, әдәби әсәрне һ.б.ш.ны). *[Җырны] Сандугачлар һәм тургайлар Матур көйгә салганнар.* Г.Зәйнашева. *Теге сиңа күрсәткән «Яңгырлы төндә» дигән шигырьне әйбәтләп рифмага салып бетердем.* М.Нәзиров // Нотага күчереп яки оркестрга яраклаштырып язу (көйне). *Ә инде халык моңнарын язу, нотага салу бары тик XX гасырда гына башлана.* Р.Вәлиев. *Ул аны бераз үзгәртә, шомарта, баета да оркестрга сала, һәм җыр шулай Сәйдәш иҗатына кереп тә китә.* Р.Батулла

44) Кайнатып пешерергә кую (ашсуны). *Ашны да шуларны уйлап ишләрәк салган иде [Маһибәдәр].* А.Гыйләҗев. *Галия ханым, шаяртып сөйләнә-сөйләнә, пилмән салырга керешкән иде, кемдер итагатьле итеп ишек шакыды.* Ф.Әһлиуллина // Пешерергә кую яки пешерү (ипине, мич ашларын һ.б.ш.ны). *--- авырлык белән исәпләшеп тормадылар: егетле кунакларны бәлеш салып, мунча ягып ашка алдылар; нәзер әйтеп, Корбан бәйрәме саен тояклы мал суйдылар, хәер-садакаларны кызганмадылар.* А.Гыйләҗев. *Инде җыенга бер-ике көн кала, хатын-кыз, нәкъ бәйрәменә хас, бөтен дирбиясын кертеп, татлы чәй ризыклары әзерләү һәм ипи салу мәшәкатьләренә чума.* Г.Галиева // Әчетергә дип кую (балны һ.б.ш. эчемлекне). *Бәйрәмгә дип сыра салу. Туйга бал салу*

45) Мунчалалык кабык, киндер һ.б.ш. нәрсәләрне җебетеп-йомшатып эшкәртү өчен суга батыру. *Габдулла аның мунчала сала торган күлдән кайтканын ишетте һәм әнисеннән Тимриләргә кереп чыгарга рөхсәт сорады.* Ә.Фәйзи. *Елга буйларында яхшы юкәлекне сайлап, ирләр һәм хатын-кызлар кул көймәләре белән юкә салырга барганнар.* Яңарыш. *Елга тармагын буып басма салу. Киндер салу*

46) Ашламаны туфракка кертү. *Комплекс 12 метр киңлектә, орлыкны 2 сантиметр тирәнлектә, астына ашлама салып күмдереп бара.* Якты юл. *Торф чыганаклары янган вакытта, бер метр тирәсе чокыр казып, бу урынга төрле минераллар салырга кирәк.* Ватаным Татарстан

47) Сугарга-тукырга дип әзерләп станга корып кую (киндерне). *Ак киндер салу. Тула салу. Салган киндерне тизрәк сугып бетерергә ашыгу* // Сугу, туку. *Бәйрәм алдыннан сөлгелек салып алу*

48) Аулый-тота торган бугалак, капкын, сөкә, ятьмә һ.б.ш.ны кую, кору. *Ни пычагыма интегеп ау салып йөрдек без!* А.Гыйләҗев. *Үзләре ел саен сөкә сала торган җиргә җиткәч, шомланып туктады, йөрәген үткен пәке белән сызып алгандай булды.*

Г.Ахунов. *Һәр салган кармакка бер балык эләктергән оста балыкчы кебек, һәр хаты белән бер кеше башын ашый торган «мәшһүр» агент-коммунистка әверелә ул.* С.Поварисов

49) Тышау, каеш, йозак кебек нәрсәне ычкынмаслык, ачылмаслык итеп бәйләп, буып, бикләп яки бүтәнчә беркетеп кую. *Кара да гына чәчне алдылар да Кулкаема богау салдылар.* Х.Туфан. *Кулыңа-аягыңа «кунак» дип атала торган тышау салынгач, үз теләгең белән йөрерсең, бар.* Ф.Хөсни. *Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен, дип уйлаган идеммени мин...* Ә.Еники // Элмәк, муенчак кебек нәрсәне кидерү, эләктерү. *Буралкы [иярсез] аттан ярсумын, Бугалак салсаң, туктамам.* Дастан. *Әйе, әйе, ул – яңа гына көтүдә йөргән, йөгән күрмәгән яшь айгыр, аның муенына корык элмәге салганнар, икенче бер ялчы атның өске иренен боргычлап тоткан.* А.Расих. *Үлсәм дә бирәсем юк Солтанны! Бирәсем юк! --- Муеныма бау салыгыз, аркама көпшәле мылтык терәгез, бирәсем юк!* Г.Ахунов. *Анысы, зур түткәй, мин әйтәм, ирләр муенына муенчак салу бөтен кызларның, тол хатыннарның иң беренче хыялы инде, аннан да саваплы эш юк инде, мин әйтәм.* Г.Мөхәммәтшин // Бастырык, эшермә, терәк яки киртә кебек нәрсәне, ишекне-капканы бикләү яки юлны ябу өчен, аркылы куеп махсус урнаштыру. *Милләтләр белән, диннәр белән Арабызга киртә салдылар.* Һ.Такташ. *[Зәйтүнә] ындыр капкасы аркылы бастырык салды: эт-кош кереп тавыкчебешләрне куркытып бетермәсен.* А.Гыйләҗев. *Эчтән терәү салган бәләкәй капканы ачып, эчкә үтәм.* М.Кәбиров // Кыршау кебек нәрсәне махсус кую, беркетеп эшләү, сугу. *Без шунда тиз генә килеп, фундаментка чаклы торбаларны казып чыгарып, чистартабыз, тишек урынга кыршау салабыз.* Туган як

50) Тизлекне киметергә яки хәрәкәтне туктатырга кирәк булганда, тормоз кебек нәрсәне тәгәрмәч әйләнмәсен өчен куллану. *Шуып кына станциядән чыккан поезд кинәт кенә пошкырып тормоз салды.* М.Мәһдиев. *Тигез асфальт юлдан Шаһгали авылы тирәсенә җитеп килә торган машина кинәт сызгырттырып тормоз салды да юл читенә чыгып туктап калды.* В.Нуруллин // Якорь кебек нәрсәне йөрешне-хәрәкәтне туктату яки тизлекне киметү өчен куллану. *Без якорь салып, кәрван җыелганын көтә башладык.* М.Юныс. --- *төрекләрнең яккан утларыннан һәм Идел уртасында якорь салып калган гарәпләрнең көймәсенең эчендәге фонарьлардан башка бары күктә чуп-чуар йолдызлар гына бар иде...* Г.Гобәйдуллин

51) Эшкә керешкәндә, коралны куллана башлау, шул корал белән эшли башлау. *Ишектән атлагач та, нәрсәне җимерергә дип бераз уйланды, туры шул читәнгә барып балта салды.* Г.Ибраһимов. *Маташалар апастыртын гына Җаныбызга хәнҗәр салырга.* Х.Туфан. *Әллә муеныма пычак салыйммы?* Р.Батулла. *Үсеп утырган агачның биленә пычкы салганда, йөрәгем әрни иде.* Татарстан яшьләре

52) Төзү, кору, җиткерү, эшләү (каралты-корылманы, эре объектларны һ.б.ш.ны). *Ярларның ике ягыннан да күпер сала башладылар, ди.* М.Юныс. *«Әгәренки әтиләр бик каршы булсалар, авылга кайтып, ике катлы өй салам да беренче катында кибет ачам», – диде.* Г.Галиева. *Яхшы җирләрне заводлар салыр өчен тартып алалар, моңарчы күрелмәгән салымнар халыкны изә башлый.* Р.Зәйдулла // Кору, эшләү-ясау (ваграк объектларны). *Мичне Рәхмәтулла абзый үзе салырга булды.* Ә.Еники. *Бу – анда килеп чыккан хисапсыз күп саранчаларны бетереп, кешеләрне ачлыктан коткарып калган акчарлаклар хөрмәтенә салынган һәйкәл.* Кошлар

53) Нигез, фундамент һ.б.ш.ны төзегәндә, бетон, цемент кебек материалны кою. *Әлеге йортның нигезе җиргә иңеп беткән, бетон салып ныгытмыйча ярамый.* Ватаным Татарстан // Төзү эшендә кирпеч, таш кебек материалны тиешенчә беркетеп кую, тезү, өю. *Эш башлангач, аларның һәркайсы үзенчә тырышты: Миңлебай карт кирпеч салды, ә Гобәй бу вакытта балчык изде, ком ташыды, кирпеч валчыкларын, җыелган чүп-чарны чыгарып түкте.* З.Зәйнуллин. *Балчыклап таш салырга осталары да табылды.* Өмет

54) Печән, көлтә, утын, бүрәнә кебек нәрсәне өеп, кибән, чүмәлә, әрдәнә һ.б.ш. ясау. *Атасы Мактанчык Гыймранның былтыр эскерт салганда сөйләп торганын үз колакларым белән ишеттем, әнкәем.* А.Хәлим. *Печән кибәне салган көн – зур рухи бәйрәм көн.* М.Мәһдиев. *Кояш күтәрелеп кыздыра башласа, тырма белән печән җыйды, чүмәлә салды.* З.Зәйнуллин // Печән, көлтә, утын, бүрәнә кебек нәрсәне кибәнгә, чүмәләгә, эскерткә, әрдәнәгә һ.б.ш. өемгә өю. *Бу ат өчен без ике дисәтинә урак урып, күпмедер печән чабып, җыеп, кибәнгә салып бирәбез.* Г.Ибраһимов. *Мәгънәвинең эшеннән бүленәсе килмәде, сәламнәрен алып, рәхмәт, егетләр, диде, инде җыелып өлгергән утыннарны яңа рәт башлап әрдәнәгә салырга кереште.* Р.Рахман. *Кипкән печәнне чүмәләгә салу – үзе бер талант.* Татарстан яшьләре

55) Карны, ләмне һ.б.ш. нәрсәне өю, берәр җиргә китереп түшәү, катлам итеп калдыру, җыебрак яткыру (җил, буран, агым тур.). *Кичәге буран кар салганлыктан, юл авыр булса да, атын юырттырып алып китте ул.* В.Нуруллин // *з-сыз.* Кар, ләм кебек нәрсәнең җил, агым тәэсире белән берәр урынга җыелыбрак түшәлүе, катлам булып ятуы турында. *...Басу өстендә кар дулкын-дулкын булып яткан иде, көртне зуррак салган урыннарда күксел күләгәләрне ярып үтеп, әнә шул дулкыннар өстеннән килә торгач, беренче скважинага килеп җиттеләр.* Г.Ахунов. *Юлга кар салган.* Р.Батулла

56) Машинаны тизлеккә кую, эшләүгә күчерү, көйләү турында. *Фаил арткы тизлеккә салды, тагын алга алдырып карады, әмма машинаның кымшанырга исәбе юк иде.* Раз. Вәлиев. *[Шофёр Газим] Машинасын хутка сала.* Н.Вахитов

57) Күкәйне организмнан чыгару (кошлар, сөйрәлүчеләр һ.б.ш. кайбер җәнлекләр тур.). *Гөлйөзем әби:*

*«Хәзрәт, менә безгә догаңны аз кыласың, быел бер үрдәгем качып салды, үрдәкләрем аз булды», – дип, пешкән үрдәк чыгара иде.* Г.Исхакый. *Бер тавыгым күкәйләрен каядыр качырып салып, кыртлап йөри башлаганые.* Г.Галиева. *Күкеләрнең күбесе йомыркаларын башка кошларның ояларына сала.* Кошлар

58) Хайваннар турында: җитлегеп бетмәгән яки ярала гына башлаган хәлендә баласын вакытыннан алда тудыру. *Иртә белән --- бия колын салган.* Т.Гыйззәт. *Зәкәрҗанның болай да әйбәт холыклы сыеры, бичара, берәр атна мотоцикл озатуында куркып-чабып кайтты да бозау салды...* М.Мәһдиев // *сөйл.* Хатын-кыз турында: шул ук мәгънәдә. *[Кыяметдин] хатынының гел эченә, башына типте. Хатыны бернечә үле бала салды.* Ф.Бәйрәмова

59) *күч. сөйл. гадәттә з-сыз.* Бик ишле, көчле яву (яңгыр, кар тур.). *– Бер ява башлагач явар инде. – Яумый хәле юк. – Бер елны да башта шулай булган иде. Шуннан соң сала башлады – тотын гына!* Ш.Камал

60) *күч.* Сугу, бәрү. *Дилбегәне болгый-болгый кычкырып җибәрдем: «На, на! Менә салырмын берне сырт буйлап!»* Г.Бәширов. *Аннары Кадрия Дездемона да түгел, буарга килә башласаң, тимер-томыр белән маңгаеңа салыр.* А.Гыйләҗев. *Солтанның сыртына салам дип, икенче мәртәбә камчысын күтәрүе булды [Мөгыйннең], кемдер аның кулыннан кысып тотып алды.* Г.Ахунов

61) *күч. сөйл.* Исерткеч эчемлекләр эчү. *Хәерлебәнат апаң әнә җылый, син гыйлем аласың, ә мин сирәк булса да эчкәлим. Салгалыйм, апаем...* А.Гыйләҗев. *Камалетдин абзый да бөлгән байлар гадәтенчә салырга бик ярата иде, мәрхүм!* Ә.Еники

62) *күч. сөйл.* Вак тәмәке, эфьюн кебек нәрсәне тел астында тотып кәефләнү өчен авызга кабу. *Әфьюн сала-сала куркаклыкка сабышып беткән мәхдүмнең шул тавыш котыны алды, ул, акрын гына барып, урынга ялгыз гына ятты.* Г.Исхакый. *Һәм ул, тынычланыр өчен, кесәсеннән кечкенә шешәсен чыгарып, тел астына насбаен салды да бер читкәрәк китеп барды.* Ә.Еники. *Насбай салган егет, урыныннан кузгала төшеп, янган утны рәтләде, читтә яткан агач башларын утның өстенә салды да баягыча тагын кырын ятты.* М.Гафури

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Эш-хәлнең тулылыгын, төгәлләнгәнлеген һәм җанлылыгын белдерә. *Үзен күрсәтергә теләп, әллә кемгә куеп йөргән тәнкыйтьче менә дигән әсәрне тетеп сала.* С.Поварисов. *– Гол! – дип үкереп салды җитмәсә тагын бер ир кеше.* Ә.Еники. *Теләсә кем сүзенә колак салу монда туры килми кебек, тагын күз сала башласаң!* Н.Фәттах

2) Эш-хәлнең кыюлык-тәвәккәллек белән башкарылуын белдерә. *Торып сөйләүче, әсәрне чәеп мактаса да, бетереп ташласа да, әйтергә теләгәнен яра да сала.* Ә.Еники. *Ашаганы тәненә йокмаса да, ярты сарыкны сыпырып сала торган иде.* М.Шабай. *– Өйләнәм! Барыбер Сәет кызы Нурданиягә өйләнәм! – дип кисеп салдым мин.* Р.Муллин. *Җәен көйдерде дә салды.* Г.Бәширов

3) Эш-хәлнең уйламыйча, кинәт, теләмәстән башкарылуын белдерә. *Ул райбашкарма кешесенә бик рәнҗесә дә, үзенең дә кайчак колхозчыларга тупас-тупас кычкырып салгалый торган гадәте юк түгел.* И.Гази

◊ **Салган башка** *к.* **салган баштан**. *– Аңламыйм! – дигән булды туры җаваптан качу юлын эзләгән Сәмигулла. – Салган башка аңламассың да шул!* Г.Минский. **Салган баштан** Исерек килеш. *Салган баштан, имеш, [Ташлытауның иң эре спекулянтларыннан берсе] базарда җырлап узган: «Колхоз тарала микән, Колхоз казала микән?»* М.Мәһдиев. *Салган баштан ире аны шулай шактый азаплый.* Ф.Бәйрәмова. *– Врач янына салган баштан керү бер дә килешми, иптәш, – диде шунда теге, минем уйларны бүлдереп.* Ә.Сафиуллин

**Сала бару** Һаман салу. *Кыз да, билгеле, үзенә карата бу җылы мөнәсәбәтне бик тиз аңлап алды һәм остазының һәр сүзен күңеленә сала барды.* Ф.Әһлиуллина. *Үзе таратасы газета-журналларны, ал, зәңгәр, ак, сары конвертлы хатларны рәтләп, ике бүлекле күн сумкасына сала бара.* Л.Ихсанова

**Сала башлау** Салырга тотыну. *Иртә белән эшкә килгәч, Габдырхай өстенә халатын киеп ала да, бая әйткәнемчә, шул холодильникта сыер, сарык түшкәләрен штабельләргә тезеп сала башлый.* Н.Дәүли. *Димәк, әлеге препаратларны куллангач, тавыклар йомырканы күбрәк сала башлый?* Безнең гәҗит

**Сала тору** Бернигә дә карамыйча салу. *Ә кар туктамый ява да ява, җил дә басылмый, юлларга карны сала тора.* Ч.Айтматов. *Милиция әбинең хилафлыкларын фаш итә, суд, аны колониягә озатырга яхшысынмыйча, штраф сала тора.* Безнең гәҗит

**Салып алу** Тиз арада салу. *Аннан тагы торып, тагы бераз салып алыр, наз таләп итеп, тагы хатынына бәйләнә башлар.* Ф.Бәйрәмова

**Салып бару** Рәттән, даими, регуляр төстә салу. *Эшләгән чакта кассага акча салалмый идем, хәзер, кирәкяракка дип, әз булса да салып барам.* Г.Мөхәммәтшин

**Салып бетерү** Барысын да, беткәнче салу. *Гайсин стакан сорап алды да калган аракысын тамчысына кадәр салып бетерде.* Х.Сарьян. *Казан белән Арча арасындагы «чугунка»ны һаман салып бетерә алмыйлар иде әле.* Г.Бәширов. *Кәрим, яр буена утырып, күн итекләрен салды, күн курткасын салды; күлмәк-ыштаннарын да салып бетергәч, шуларның барысын ашыгып кына чалбар каешы белән бәйләде дә язгы ташудан соң әле тонykланып та җитмәгән Зәй суына кереп китте.* Г.Ахунов // Күп итеп салу. *Яңа Кәлимәткә әллә нинди гаражлар, автовокзаллар, трактор парклары салып бетергәннәр.* Г.Ахунов

**Салып җибәрү** Тиз арада, кискен генә рәвештә салу. *Егетләрнең өченчесе – карап торуга әүвәлге ике егеткә караганда яшькә зуррагы – көпесен аркасына яба төшеп кырын ятты*

*һәм, --- сул як кулының учына бер чеметем насбай алып, --- аскы ирене белән тешләре арасына салып җибәрде дә янган утка карап уйга калды.* М.Гафури. *[Мәхүбә апа:] – Көн бик кызу, мич ягарга кушмыйлар, – дип сөйләнә-сөйләнә, аш салып җибәрде.* Х.Сарьян. *Тик бер генә тапкыр, мин көн буена каядыр югалып торып, кичкырын гына кайтып кергәч, ул, ниһаять, түзмәде: бик җилле генә минем яңакка салып җибәрде.* Ә.Еники

**Салып карау** Тикшерү-белү максаты белән салу. *Тик, егеткә күпме генә ау салып карамасыннар, эш барып чыкмады.* Н.Көбәш. *Ләкин аларны ярату ике төрле, һәм аны үлчәүгә салып карап та булмый.* Ватаным Татарстан. *Шундыйларның тагын берсенә кармак салып карадым.* Безнең гәҗит

**Салып кую** Тиз арада салу. *Әнинең акаеп каравына игътибар итмичә, әти аракы шешәсен ачты. --- Сүзсез генә салып куйдылар.* Р.Зәйдулла. *Комсомол билетын шул өстәлнең тартмасына салып куйдым.* Р.Зәйдулла. *– Япан кырда алачык салып куйгансыз икән, – диде Идрис.* А.Гыйләҗев

**Салып тору** Хәзерге момента салу яки гел, һәрвакыт салу. *Менә ул да шигырь чыгара иде, ә этисе гел акча салып торды, күчтәнәчен җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Ярый, акчасын салып тордың. Ә минем хәлем белән кызыксындыңмы берәр?* М.Кәбиров. *Бит юганда, апай миңа үзе генә юына торган, әтәч кикриге кебек алсу төсле, хуш исле «Гөлҗиһан» сабынын биреп, үзе су салып торды.* Г.Бәширов

**Салып чыгу** Берсен дә калдырмыйча, барысына да салу. *Таминдар әфәнде --- рюмкаларга коньяк салып чыкты.* Г.Ахунов

**Салып яту** Хәзерге моментта салу эше белән мәшгуль булу. *Башта алар әйбәт кенә эшләделәр, хәзер әллә колхозның акчасы бетте, әллә төзисе әйбер калмады, әрмәннәр инде вак-төяк эшләрдә генә йөриләр, яртысы район үзәгендә персидәтелгә катижмы, матижмы диләр, өч катлы йорт салып ята иде.* Р.Зәйдулла. *Дөрес, башкача мөмкин түгел хәзергә, аны мин үзем дә аңлыйм, чөнки совхоз оешып та өлгермәгән, беренче нигез ташларын гына салып ятабыз.* М.Шабай

**САЛУ** II *ф.* 1) Өс-башка яки кулаякка кигән, таккан, бәйләгән һ.б.ш. нәрсәне чишеп, ычкындырып яки бөтәнчә кире алу. *Бүген гүя миңа бик кирәкле Кеше кебек, ашыга-ашыга, Галошларың салмый, ни дип инде Килеп кердең, атаң башына?!* Һ.Такташ. *Шигырь бүген Сезне нәләтләүне Бүрек салмый гына башкара!* Х.Туфан. *Карт, маңгаен җыерып, нидер көтеп, аңа таба карап торды да эшләпәсен салды.* А.Гыйләҗев. *Күзлекләрен бер салалар, бер кияләр.* Р.Сәлим // *сөйл.* Өсбаштан, аяк-кулдан киемен алу. *Шуңа күрә Ибраһимов өстен салмаска булды.* С.Поварисов. *Өсләрен салсалар да, кашнены муеннан алу юк.* Ә.Еники

2) Йөгән, тышау, камыт кебек нәрсәне ычкындыру, шудырып чыгару, ташлау, аннан арыну (хайван тур.). *Җизнәсеннән чыгып, Мортазага яллану – бу бер камытны салып, икенчесен кию икәнлеген, ниһаять, төшенеп алды ул.* Ә.Фәйзи. *Гел йөгән белән күреп ияләнгән ат янына йөгәнен салгач барырга куркасың.* М.Мәһдиев. *Атның авызлыгын салуы. Бәрәннең кешәнен салуы. Бозауның муенчагын салып качуы*

3) Мөгез, тире һ.б.ш.ны ташлау. *Тик менә Каргалы үзе генә, мөгезен салган карт сыер шикелле, күпмедер вакытка кысыр кала.* Ә.Еники. *Нәзек тавышлы берәү: – Мөгезен салган поши булган ич ул, мөгезе булмагач, тибеп киткән ул аңа! – диде.* М.Шаһимәрдәнов

4) Кабык, тышча һ.б.ш.дан арыну (орлык һ.б.ш. тур.). *Гөл төбендә ниндидер орлык тишелгән, сузаеп үскән, әмма кабыгын сала алмаган.* Ш.Галиев

5) *күч.* Югалту, сакламау (табигый төсне, чырайны һ.б.ш.). *Аның битен вак җыерчыклар каплаган, чәче агарган, ә тешләре – матур булып тезелеп торган вак кына тешләре – һаман да төсен салмаган иде әле.* Г.Бәширов. *Аның күп борчылу күрүдән инде төс сала башлаган йөзенә матур гына булып алсулык йөгерде.* Ф.Хөсни. *Ике тәрәзәнең берсендә (берсендә генә дип хәтерлим), кәҗәләрнең буе җитмәслек итеп, кайчандыр ак булып, хәзер инде төсен салган пәрдә эленгән.* Ватаным Татарстан

**Сала башлау** Салырга тотыну. *...Кичен, күз бәйләнгән вакытларда, бите кызарып янган Гыйлемҗан Тукай янына килеп керде дә итеген сала башлады.* И.Нуруллин. *Шәһәр урамындагы агачлар, «безнең вакытыбыз үтте инде» дигәндәй, оялып кына яшел күлмәкләрен сала башладылар.* Г.Хөсәенова

**Салып ату** Тиз һәм кискен хәрәкәтләр белән салу. *Ә инде ике-өч туктаусыз узуга, шундый итеп сыланалар ки, ирексездән чалбарны салып атасы килә башлый.* З.Мәхмүди. *Тәрәзәдән күзләп торган Әнвәрне шаккатырган тагын бер хәл булды: Нури, ялт кына күлмәген салып атып, аркасын, күкрәген, битен уч-уч кар алып уа, ышкый башлады.* Г.Әдһәмова. *Итекләрне салып аттым да, мендәргә капланып, тавышсыз гына балавыз сыктым.* Гөлшәһидә

**Салып кую** Тиз генә яки алдан салу. *Укытучы апабыз аяк киемнәрен салып куйды да, безне берәм-берәм кочтырып, елга аркылы ташыды.* Б.Ислам. *Кайберсе көлеште, кайберсе игътибарга алмады, бик сирәге генә авырлык белән баш киемнәрен салып куйды.* Ватаным Татарстан

**Салып ташлау** *к.* **салып ату**. *Ул чикмәне белән бүреген салып ташлады да каенесе артыннан басты.* М.Галәү. *Ихтыяр пинҗәге белән ботинкасын салып ташлады да, өйдән алып килгән ыргакны чалбар каешына эләктереп, карт өянке ботагына башта куллары белән асылынды, аннары, бераз атынып торгач, ботакны аяклары белән кочаклап алды да мәче җитезлеге белән җәһәт кенә өскә менеп басты.* Р.Вәлиев

**Салып тору** Сөйләм вакытында салу; нәрсәнедер салып, күпмедер вакыт үткәрү. *Бу елларда исә җылы киемнәрне салып торырга туры киләчәк.* Ватаным Татарстан

**САЛУ** III *и.* Кышкы юлның авышкан урыны. *Кышкы атлы юлда чалулар, салулар дип тә әйтәләр, була.* М.Хуҗин.

*Болай, шәкертнең кайбер сикәлтәләрне бик оста борылып үтүенә дә, кай салуларда, каушабрак китеп, дырык-дырык рессорлар тетрәнүенә дә остазның бер үк дәрәҗәдә битараф калуы сәеррәк сәерлеккә...* Р.Төхфәтуллин

**САЛУЛА́У** *ф.* Салуда (III) таеп кыйшаю, янтаеп китү (транспорт чарасы тур.). *Юл юеш, пычрак, арба әле уңга, әле сулга салулый ---.* Р.Зәйдулла. *Чана, салулап, сулга китеп барды, бүренең ачылган авызы шалт итеп һаваны тешләп калды.* Ә.Дусайлы. *Я пычракка чума, я уңга-сулга салулый, я көпчәкләре бер урында әйләнә.* Ватаным Татарстан

**Салулап алу** Кыска бер вакыт эчендә салулау. *Ул кинәттән генә салулап алды да тыелгысыз бер көч белән түбәнгә шуыша башлады.* А.Тимергалин. *КамАЗ туры юлда салулап алды.* Ф.Яхин

**Салулап китү** Кинәт салулау. *Минем чана түбән таба салулап китте.* Г.Ибраһимов. *Нәсимә исемле артистка утырган чана салулап китә, һәм Нәсимәнең биләүдәге баласы чанадан тәгәрәп төшә дә боз өстеннән бәкегә таба шуып китә.* Р.Батулла. *Шул тауны төшкәндә, бормалы җирендәге комы йомшарган, һәм мотоцикл салулап китте.* Безнең гәҗит

**Салулап тору** Гел, һәрвакыт салулау; хәзерге моментта салулау. *Шуңа күрә бу мәсьәләдә салулап тормыйк.* М.Кәбиров

**Салулап яту** Озак вакыт салулаган хәлдә булу

**Салулый башлау** Салуларга тотыну. *Машина бераз җай гына бара да салулый башлый.* Кызыл таң

**САЛУЛЫ** *с.* Салулары (III) булган. *Язмышының салулы чоңгылларын исәнимин кичеп чыга алган Наис әдәбиятка булган таләпчәнлеге, фәнни карашы, рухи тоемы белән безне – шигъри даирә вәкилләрен дип әйтимме инде – гел киеренкелектә тота белде, җаваплы булырга өйрәтте.* Зөлфәт. *Салулы борылыш*

**САЛФЕТ** *и. ит. иск. к.* **салфетка**. *Анлар [чебеннәр], жу-у-у итеп торып чәйгә, ашка төшеп, бабайны җирәндергән кеби, бөтен диварларны, сөлгеләр, салфетларны былчыратырга тотындылар.* Г.Исхакый

**САЛФЕТКА** *и. ит.* Ашаганда яки ашап бетергәч, кулларны, иреннәрне сөртеп алыр өчен кулланыла торган кечкенә сөлге яки кәгазь кисәге; тастымал. *Ул кәгазь салфеткалар белән аракыны корытырга тотынды, җиңе белән ашка тыгылып чыкты.* А.Гыйләҗев. *[Сабира:] «Кичәдән бирле шушы нәрсәләргә кулым кычый, юып ташлыйм әле үзләрен, булмаса!» – дип сөйләнә-сөйләнә, керләнгән сөлгеләрне, салфеткаларны, савыт-саба сөрткеч тастымалларны бер өемгә җыя да башлады.* Ә.Еники

**САЛЧЫ** *и.* Сал бәйләү һәм агызу эшләрендә эшләүче. *Ага Агыйдел, Кала ярлары, Бара салчылар, Бора салларны.* Н.Исәнбәт. *– Бу минем племяш, абыйның улы, Солтан атлы, – диде Шәяхмәт абыйсы. – Салчылар әртилен ишәйтәм. Дөньяны таный торсын, диюем.* Г.Ахунов. *Әтиләре Фәхрисламны салчылар кыйнап үтерә.* Кызыл таң

**САЛЫМ** *и.* 1) Дәүләт тарафыннан билгеләнеп, юридик һәм физик затлар тарафыннан түләнелә торган акчалата мәҗбүри җыем; налог. *Бигрәк тә салым вә ясак күләме артты, хак вә бәя үсте.* Ф.Яхин. *--- казна салымнарыннан башы чыкмый иза чиккән ярлы-ябагай кулы белән һөнәргә тотына: итек баса, чыпта суга ---.* Г.Ахунов. *Җылы якларда җәннәт тормышы вәгъдә итеп, салым җәтмәсендә чәбәләнгән игенченең кызын юк кына бәягә алып, аларны көтүләре белән үзбәкләргә илтеп сатканнар.* Р.Зәйдулла

2) *махс.* Бер салуда, бер оч буйлыктан сугыла торган киндер күләме. *Тоташтан ике салым киндер сугу. Салымны зур итү*

**САЛЫМЧЫ** *и.* Салым җыючы. *Йөзбашлары һәм салымчылар пошаманлы хәбәрне иң әүвәл әнә шулар тарафыннан ирештерде.* В.Имамов

**САЛЫНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **салыну** (*2–4, 6, 7 мәгъ.*) // Түбәнгә сузып асылындыру (аякны һ.б.). *Йөргән вакытта бер иңбашын төшеребрәк, озын һәм каба кулларын һич хәрәкәтләндермичә, ике ягына аскан күсәкләр кебек салындырып, акрын һәм эре генә атлап йөри иде.* Ш.Камал. *Солтан, күзен кулы белән уа-уа, ялан аякларын сәке йөзлегеннән салындырып торып утырды.* Г.Ахунов. *Ул чыкканда, Алмабикә аякларын салындырып утыра иде.* С.Поварисов. *Эт телен салындырган*

**Салындыра башлау** Салындырырга тотыну

**Салындыра төшү** Әз генә, бераз гына салындыру; тагын да ныграк салындыру. *Айдагы Зөһрә кыз, айның бер читенәрәк килеп, башын да бераз салындыра төшкән кебек, Маһисылуны күзли, ачыграк күрергә тырышкан кебек карый иде.* Н.Думави. *Ике тапкыр уйнап чыккач, Салих туктады һәм, хәлсезләнгәндәй, иңбашларын салындыра төшеп, бераз тынып торды.* Ә.Еники

**Салындырып йөрү** Гел салындыру. *Бичаралар, температуралары күтәрелеп, ике-өч көн башларын салындырып йөриләр, тәгам ризык капмыйлар.* М.Мәһдиев

**Салындырып кую** Тиз генә салындыру яки салындырган хәлгә китерү. *Габдулла, мәдрәсә эчендә үзенең түбәтәен салып, яланбаш йөри башлады. Һәм чалбар балагын читек эченнән чыгарып, читек өстеннән салындырып куйды.* Ә.Фәйзи. *Аның [кашненың] бер башын алга, икенчесен артка салындырып куялар.* Ә.Еники

**Салындырып тору** Салындырган хәлдә булу

**САЛЫНКЫ** *с.* 1) Салынып (*2, 3 мәгъ.*) тора торган. *Салынкы кабаклары күтәрелде, симез йөзенә шатлык чыкты.* Г.Ибраһимов. *Кечерәк буйлы җыйнак кына карт, иңбашлары әзрәк салынкы, кара-көрән муенында аркылы-торкылы сызыклар.* Ә.Еники. *– Һе, – дип, салынкы мыек чылгыен сыпырып куйды Мамаев.* А.Тимергалин. *Сарайның салынкы ишеге төбенә җиткәч туктады Миркадәм, минем ияреп эчкә керүемне теләмәде.* М.Хуҗин

2) Сүрән, болытлы, яңгыр алдындагы кебек (көн, һава тур.). *Көн салынкы. Авыр соры болытлар авыл өстенә бик*

*түбән төшкәннәр.* Г.Гобәй // Авырайган, салмак, җиргә шактый якын булган (болытлар тур.). *Тау-тау ак болытлар, куерып, салынкы кара-кучкыл яңгыр болытларына әвереләделәр.* М.Галәү. *Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар.* Ә.Еники

3) Арыганлыкны яки иренгәнлекне күрсәтә торган, әкрен (адым, эш-хәрәкәт тур.).

4) Әкрен эш-хәрәкәт итүчән, кабаланмаучан, җитезлек күрсәтмәүчән. *Боларның барысын да мин юньле тотарга тиеш ләбаса, ханнар сайфиягә сирәкләгәч, салынкы йөргәнмендер шул...* М.Хуҗин. *Аты салынкының үзе дә салынкы, диләр.* Казан утлары

5) Төшенке, боек (күңел, кәеф тур.)

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик әкрен яки иренеп, теләр-теләмәс кенә (эш-хәрәкәт итү тур.). *Хәзрәтләрнең әзерләп килгән чыгышлары ничек кенә кызыклы булмасын, җыелыш, ни кызганыч, бик салынкы гына барды.* Шәһри Казан. *Мәгълүмат чаралары үз эшләрен салынкы башкарган*

2) Боегып, төшенкелеккә бирелеп (йөрү, эшләү тур.)

**САЛЫНКЫЛАНУ** *ф.* 1) Салынкыга (*1 мәгъ.*) әйләнү, салынып тора башлау. *Колак салынкылану. Ишек салынкылану*

2) Болытлау, сүрәнләнү, салыну (көн, һава тур.). *Яңгыр алдыннан көн салынкылану*

3) Бик акрынаю, сүлпәнләнү, пассивлану (адым, эш-хәрәкәт тур.). *Талчыккан кулның хәрәкәтләре салынкылану*

4) Әкрен эш-хәрәкәт итүчәнгә, пошмаска әйләнү, сүлпәнләнү; җитезлеге кимү. *Эш ахырына таба салынкылана башлау*

5) Төшенкеләнү, боегу, кәефсезләнү (кеше тур.)

**Салынкылана башлау** Салынкыланырга тотыну

**Салынкыланып китү** Соңгы вакытта салынкылану

**Салынкыланып тору** Хәзерге моментта яки гел, һәрвакыт салынкы булу

**САЛЫНКЫЛЫК** *и.* Салынкы булу

**САЛЫНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **салу** I **1.** (*1–6, 8–10, 12–28, 30–40, 42–54, 56, 61, 62 мәгъ.*). *Мәчет әле салынып бетмәгән, әмма аның кыяфәтенә Мәскәүдәге кемсәләр гел дә битараф түгел инде.* Р.Зәйдулла. – *Уйна, кызым, уйна, туктама, – диде дә, әле моңарчы берсе дә ишетмәгән сүзләргә салынган җырын сузды.* Г.Галиева. *Фоторәсем шул ук көнне Яңа Актауга – әти-әнигә адресланып, почта ящигына салынды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Сузылып яки тартылып, бөгелеп, түбәнгә таба төшеп тору. *Инде, әфәнделәр, мин сезгә бер сөаль бирәм: сезгә урамда җөргән вакытыгызда, бишбилле бишмәтле, тездән генә чалбарлы, кырган мыек, озын сакаллы, чалбар бавы салынган, яшел читекле бер татар очраганы бармы?* Г.Тукай. *Хат тоткан куллары хәлсезләнеп аска салындылар.* Г.Галиева. *Ә орнитоз белән авыручы күгәрченнең гадәттә канаты салынган, каурыйлары тырпайган була.* Шәһри Казан

3) Иелеп, бөгелеп төшү (ботак, баш һ.б. тур.). *[Зөһрәнең] Өстендә киң ак күлмәк, башы ачык кәвенчә, аркасын азрак бөкрәйтеп, иңбашларын төшеребрәк, пәжегән гөл кебек салынып утырган...* Ш.Камал. *Җил минем уйларымны иләртеп алып китә, керфекләрем авыраеп ябыла башлый, башым күкрәгемә салына, кинәт үзем гырлаганны үзем ишетеп, сискәнеп башымны күтәрәм.* А.Гыйләҗев. *Минбәдәр апа белән иркенләп хушлашырга өлгермим, өзепөзеп машина кычкырта, җилкәләре салынган бәләкәй хатынга кузовтан гына кул болгыйм.* Н.Гыйматдинова

4) Авыша, янтая башлау (кибән, каралты һ.б.ш. тур.). *Өй бер якка салынып тора, тәрәзәләре ватык, эче кабер кебек караңгы иде.* Ш.Камал

5) Күтәрә алмаслык хәлгә килү; башкаларга салу (гәүдә авырлыгы тур.). --- *әле узган төн генә сине куркыткан Хөлләбетдин абзыйның таякка салынган бөкрәйгән гәүдәсе дә,* --- *Фәләхетдин дә шул сихри шалаш янында халык әкиятләрендә генә очрый торган серле каһарманнар булып күренәләр.* М.Мәһдиев

6) Нинди дә булса эшне кемнеңдер яки нәрсәнеңдер башкаруына исәп тоту. *И кызым, бер дә генә дә үзеңне үзең кайгыртмыйсың шул, бигрәк тә әбиеңә салынасың инде!* Г.Бәширов. *Пианино, суыткыч, телевизор ише әйберләрне күтәрергә анда аркандыр, баудыр ише әйберләре кирәк кадәр бар, күчерешкәндә, ул кешегә салынмый, авыр әйберләрне яшьләрдән ким күтәрми.* А.Гыйләҗев. *Хан кызы түгелсең, кешегә салынырга өйрәнмә.* М.Маликова

7) Болытлау, сүрәнләнү, салынкылану (көн, һава тур.). *Көн салынган* // Куеру, авыраю, салмаклану (болытлар тур.). *Болытлар, куерып, тоташка әйләнделәр, салындылар, һәм кыйгачлап яңгыр коярга тотынды.* А.Гыйләҗев.

8) Үзен үзе билгеле хәлгә дучар итү, берәр рухи халәткә бирелү, сабышу. – *Аерым бәндәләр, – дип яза ул, – бөтенләй этлеккә салынган...* Я.Абдуллин

9) Сыйфатлардан һәм *-ган, -мыш* формаларыннан соң килеп, шулай кылану, юри эшләүне белдерә. *Каенанасы аның бу халәтен сизмәде дә кебек, әллә сизеп тә сизмәмешкә салындымы?..* Г.Галиева. *Сабира соңгы сүзләрне ишетмәмешкә салына.* Ф.Бәйрәмова. *Белсәләр дә белмәгәнгә салына бит алар махмыр диган нәрсәнең җәфаларын!* Г.Мөхәммәтшин

**Салына бару** Торган саен ныграк салыну. *Ул аны хәзер әйтер, һаман иелеп, күкрәгенә салына барган авыр башын аз гына күтәрер дә менә-менә әйтер шикелле.* Г.Бәширов

**Салынып бетү** Тәмам салыну. *Урам башын өлгерткән дә инде, тик эчке башы гына салынып бетмәгән әле [өйнең]...* Ә.Еники

**Салынып тору** Әле, хәзер салынган булу яки һәрвакыт, гел салыну. *Көн ачык түгел, болытлар салынып тора, һавада юешлек, яңгыр исе аңкый иде.* Ш.Камал. *Әнә ул кайларга кадәр җәелгән, әнә нинди алмалар, нинди чияләр, агачларын сыгылдырып, салынып торалар!* Г.Бәширов. *Ул ефәк эшләпә кигән, муенында күбәләк галстук, түш кесәсеннән сәгать чылбыры салынып тора, ә кулына таяк тоткан иде.* А.Тимергалин

**Салына төшү** Бераз салыну; тагын да ныграк салыну. *[Авыру] Нәҗип бара алмады. Өйдән чыгып, берничә адым китүгә чайкала башлады. Аны ике малай ике култыгыннан җитәкләделәр. Ул, барган саен, иптәшләренә күбрәк салына төште.* Г.Гобәй

**Салынып яту** *сөйл. к.* **салынып тору**. *[Апай] Аңа [әтигә] салынып ятмый. Үз өс-башын үзе карый.* Г.Бәширов. *Якты полоса әкренләп бире таба күчте, салынып ята торган Яңа Кәлимәтнең төзелеш мәйданнарын, тау-тау өелгән ташларын, төрле почмакларда муеннарын күккә сузган кран-манараларын берәм-берәм яктыртып, тикшереп-барлап узды.* Г.Ахунов

**САЛЫШ** *и.* 1) *сөйл.* Салу I **1.** (*1–4, 6, 8, 10, 12, 16, 17, 20–27, 30, 33, 37, 44, 51, 52, 59, 61, 62 мәгъ.*) гамәле, салу процессы. *Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың, ә мунчада – карта.* А.Шамов. *Аулак өйләрдә тәңкә салыш, арка сугыш уеннарында, [апай] ут борчасы шикелле, уйнаклап кына йөри.* Г.Бәширов. *Без, малайлар, үзара сугыш башлар алдыннан: «Алыш бармы, салыш бармы? Егылган еламасын», – дибез.* М.Кәрим

2) Салышу (*5 мәгъ.*) күренеше, салышу гамәле

**САЛЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **салу** I **1.** (*1–4, 6–9, 12–17, 20–23, 26, 27, 30, 37, 38, 42–50, 52–54 мәгъ.*). *Татар милли театрының нигез ташларын салышуда да Ф. Әмирханның роле зур.* Р.Әмирхан. *Гомер буе кешеләргә йорт салышты, тәрәзә рамнары, ишекләр ясашты.* Н.Гариф

2) *к.* **салыну** (*5 мәгъ.*). *Ата-анасына салышып ятучы егет яки кыз*

3) *-лыкка* формасыннан соң килеп, берәр төрле рухи халәт иясенә әверелү, шуңа бирелү, сабышуны белдерә. *Бу тормыштан туйган хатын эчкечелеккә салыша, малайны ире белән калдырып, өйне ташлап китә.* Р.Батулла. *Дус кызлары шаяртканга да, арбадагы Фёдорның, исереккә салышып, күкрәкләрен кыскалауларына да әһәмият бирмәде.* Ф.Яхин

4) Сыйфатлардан һәм *-ган, -мыш* формаларыннан соң килеп, шулай итkәндәй кылану, шулай эшләү. *Белмәмешкә салышып кына Син нәрсәдер иҗат итәсең.* Х.Туфан. – *Шулаен шулайдыр, – диде Исхак, исе китмәгәнгә салышып, ә үзе икеләнә калды.* А.Гыйләҗев. *Миңа нишләргә? Ишетмәмешкә салышып, йоклаган кешедәй ятаргамы, әллә апаны аралаган кыяфәт ясаргамы?* Р.Зәйдулла

5) Күмәк мәҗлес әзерләү, ярдәм оештыру һ.б.ш. очракта берәр максат белән җыешу. *Студентлар, барлыюклы акчаларын салышып, билетлык сума җыйдылар һәм, институт президенты рөхсәте белән, Мулланурны ашыгыч рәвештә Казанга озаттылар.* А.Расих. *Юлны дәвам итәр өчен, акча салышып, бер көймә сатып алалар.* Һ.Салихов

**Салыша башлау** Салышырга тотыну. *Соңгы вакытта, чынын әйтим, безнең буынны бераз күрмәмешкә салыша башладылар бугай.* Р.Вәлиев

**Салышып бетерү** Салышу эшен тәмамлау

**Салышып йөрү** Һәрвакыт, һәр җирдә салышу

**Салышып тору** Даими салышу яки хәзер салышу

**СА́ЛЬДО** *и. ит. махс.* Бухгалтериядә: акчалата керемнәр белән чыгымнар арасындагы аерма, шундый калдык. *Кадрия укый торган дебет, кредит, сальдолар ире сөйләгәннәрдән шактый ерак, шуңа күрә ул ире сөйләгәннәр белән генә рухланып яши.* А.Гыйләҗев

**САЛЬМОНЕ́ЛЛА** *и. ингл.* Сальмонеллёз, корсак тифы, паратиф авырулары килеп чыгуга сәбәпче бактерия. *Табиблар иттә сальмонелла тапкан.* Ватаным Татарстан

**САЛЬМОНЕЛЛЁЗ** *и. ингл.* Сальмонеллалар сәбәпле килеп чыга һәм гомуми интоксикация, бизгәк тоту, эчәклек функциясенең бозылуы һ.б.ш. симптомнар белән характерлана торган йогышлы авыру. *Көчле эчәк инфекциясе, сальмонеллёз, дизентерия авырулары таралуы бар.* Шәһри Казан

**СА́ЛЬТО** *и. ит. спорт* Сикергәндә һавада алга яки артка таба ясалган мәтәлчек. *Алар сикерә, сальто ясый, мәтәлчек ата.* Ватаным Татарстан

**САЛЮТ** *и. фр.* 1) Тантаналы сәламләү яки хөрмәтләү. *Татарлар арасыннан яшькә иң өлкәне булган Гыймади Басыйры, кабер күмелеп бетеп, мылтыклардан атып салют биргәч, мөселманнарга калырга кушты.* З.Зәйнуллин. *Бүген Мәскәү безнең гаскәрләр хөрмәтенә 200 дән артык орудиедән салют бирде.* Кызыл таң. *Артиллерия салюты*

2) Пионерларның махсус сәламләү ишарәсе. *Ә шигырь, шушы ике юлыннан ук күренеп тора, әллә ни шәптән түгел инде – мин ул вакытта артиллерия салютын пионерлар салютыннан да аерып бетерә алмаганмын.* Кызыл таң

3) Ниндидер бәйрәм уңаеннан бик күп фейерверкларның берьюлы атылуы. *Казан шәһәре үзенең икенче меңьеллыгына баскач, төнге уникедә бәйрәм салюты башланды.* Татарстан яшьләре

4) *сөйл.* Күрешкәндә сәламләү сүзе буларак кулланыла; сәлам. *Ә, синме? Салют, картлач. Яралдыңмы?* А.Гыйләҗев

◊ **Салют бирү** 1) Ут коралыннан атып, кылыч, мылтык, флаг күтәреп яки башкача сәламләү яки хөрмәт күрсәтү. *Берлин өчен сугыш тәмамлангач, Рейхстагта салют биргәндә, Хуҗалары белән кочаклашып, Атлар елый иде тирәмдә.* Г.Гыйльманов; 2) Пионерларның, бармакларын сузып бербергә тидергән хәлдә, уң кул очын баш өстенә күтәрүе. *Комсомолларга Салют бирәбез. Алмашка киләбез!* Һ.Такташ

**САЛЮТЛА́У** *ф. сир. к.* **салют бирү**. *Салютлап, бер тавыштан тантаналы вәгъдә бирү*

**Салютлап алу** Тиз арада салютлау

**Салютлап тору** Әледән-әле, даими яки хәзерге моментта салютлау

**Салютлый башлау** Салютларга керешү

**САЛЯ́МИ** *и. ит.* Ысланган каты колбаса төре. *Фәлән үлчәмдәге джинс чалбар кирәкме – рәхим ит, нәфесең салями колбасасы сорыймы – баш өсте!* Татарстан яшьләре

**САМАВАР** *и. рус к.* **самавыр**. *Әнисе, кая, самаварыңны яңарт әле.*

Ә.Еники. *Гөлмиясе самаварына су салырга да онытып басып тора.* Н.Гыйматдинова. *Хәзер самаварымны куям, әзрәк хәл җыегыз.* З.Зәйнуллин

**САМАВЫР** *и. рус* Үзәктәге утлыгына күмер ягып, су кайната торган кранлы металл савыт. *Башта гадәтчә самавыр мәйданга чыкты.* М.Акъегет. *Самавыр гаеткә дип ачылган [чистартылган], самавыр көлә-көлә җырлый.* Г.Исхакый. *Әйдә, булмаса, карчык, самавырыңны яңартып җибәр, кучтәнәчләр белән тәмләп чәй эчеп алыйк.* Г.Галиева

◊ **Самавыр яңарту** Сүнгән һәм суына башлаган самавырга күмер өстәп, суын кайнарлату яки яңадан кайнатып чыгару. *«Туйдык, туйдык инде», – дип тартынсалар да, Гөлйөзем әби тагы кайнаган су берлән самавырны яңарткач, тагы эчәләр иде.* Г.Исхакый. *Үкүбала, ирен көтеп, инде берничә тапкыр самавыр яңартты.* Ч.Айтматов

**САМАВЫРЧЫ** *и.* 1) Самавыр кую, чәй әзерләп китерү эшләрен үтәүче хезмәтче. *Аның атасы авылдан самавырчы малай булып килеп, тора-тора абыстайга ярап китеп, егерме-утыз ел эчендә миллионлы чәй фирмасының хуҗасы булган Борһанетдин абзый түгелме соң?* Г.Исхакый. *Күп тә үтмичә, [приказчик] самавырчы малайлыктан «Печән базары бае»лыкка тәрәкъкый итте, ди.* Г.Тукай

2) Самавыр ясап, яки төзәтеп, яисә шуның белән сәүдә-кәсеп итеп яшәүче. *Самавырны самавырчыга биреп төзәттерү*

**САМАВЫРЧЫЛЫК** *и.* 1) Самавырчы (*1 мәгъ.*) вазифасы һәм хезмәте

2) Самавырчы (*2 мәгъ.*) кәсебе һәм хезмәте. *Самавырчылык белән көн күрү*

**САМАГУН** *и. рус сөйл. к.* **самогон**. *Мин, Ычтапан Митрич, дөресен әйткәндә, самагунга дип килмәдем.* Г.Ахунов. *Безнең самагунны кем түкте?* Н.Гыйматдинова

**САМАЙ** *с. рус диал.* Ышанып эш тапшырырлык яшүсмер. *Самайларга да җиң сызганып эшкә тотынырга туры килде: тирәнрәк буа кирәк иде аларга!* А.Гыйләҗев

**САМАН** *и.* **1.** Үзле балчыкка салам яки тирес һ.б.ш. нәрсә кушып изелгән катнашма һәм шуннан ясалган кирпеч. *Түткиләре алар килгән шатлыктан нишләргә белми, туганнарын, өерелтә-өерелтә, дүрт почмаклы бүрәнә өйнең әллә саманнан, әллә таштан салынып акшарланган алгы ягына алып керде.* А.Хәлим. *Краснодар шәһәре читендә үзе саман изеп, шуннан салып кергән кечкенә өйдә яши.* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул катнашмадан яки шуннан сугылган кирпечтән эшләнгән. *Саман йортның үз уңайлыгы бар: ул җәй көне салкынча була, кыш көне җылы тота икән.* Ф.Бәйрәмова. *Саман диварлар эченә яшерелгән тар, караңгы бүлмәләрдән салкынча шом бәреп тора.* Г.Гыйльманов

**САМАНЧЫ** *и.* Саман ясаучы, шуннан кирпеч сугучы. *Мансур, тәҗрибәле саманчы буларак, Бакыйга кайсы төшне ныграк таптарга, ничек таптарга кирәклеген өйрәтте ---.* Н.Фәттах

**СА́МБА** *и. порт.* 1) Кызу-кызу хәрәкәтләр ясап, позицияләрне бик еш үзгәртә-үзгәртә башкарыла торган ритмлы бразилия халык биюе. *Самба биючеләр*

2) Бразилия милли мәдәниятендә музыка, җырлау һәм биюне берләштерә торган музыкаль жанр

**СА́МБО** *и. спорт* [русчадан: *самооборона без оружия* дигәннең кыскартылмасы] Авырттыру алымнары да кулланып башкарыла торган махсус көрәш. *Менә кайчан ярап куясы аңарга мәктәптә өйрәнгән самбо!* Г.Бәширов. *Иртән торып физзарядка ясыйм, салкын су белән билгә кадәр юынам, теш, ботинка чистартам, колак, чәч, баш юам, гер күтәрәм, фототүгәрәккә, фехтованиегә йөрим, самбоны өйрәнәм.* Г.Мөхәммәтшин

**САМБОЧЫ** *и. спорт* Самбо спорты белән шөгыльләнүче. *– Ә минем дәү әтием самбочы, – ди Дима Мөхәммәтҗанов.* Сабантуй. *Быелгы турнирга да Русиянең төрле почмакларыннан илнең иң көчле самбочылары килгән иде.* Татарстан яшьләре

**САМИ** *с. гар. к.* **семит**. *Сами телләр*

**САМИМИ** *с. гар. кит.* 1) Эчкерсез, риясыз, саф күңелле. *Һай, ул бала чаклар, гүзәл, самими һәм артык беркатлы уйланыла торган гамьсез чаклар!* И.Салахов. *Шунда Альберт Марленович үзен самими бала сыман сизә, кыз-хатынга сыенасы, итәгенә башын куеп иркәләнәсе килә, аның һәр әйткән сүзен җөпләп, ияреп йөрергә дә риза ул.* Р.Зәйдулла

2) Эчкерсезлек-риясызлыкны, саф күңеллелекне белдерә, күрсәтә торган. *Бу самими сораудан Томмазо каушабрак калды.* А.Тимергалин. *Хәер, Мәгъҗәннең Гөлсемгә булган хисләре самими, эчкерсез, чын йөрәктән булгандыр...* Р.Зәйдулла // Самимилеккә, эчкерсезлеккә нигезләнгән. *Без яңа гына белешкән кешеләр булсак та, мәҗлесебез бик тиз арада бик самими, әллә кайчаннан бирле бер-беребезне белешеп килгән дуслар мәҗлесе шикелле сурәт кәсеп итте.* Ф.Әмирхан

**САМИМИЛЕК** *и. кит.* Эчкерсезлек, риясызлык, саф күңеллелек. *Ниндидер балаларча беркатлылык һәм эчкерсез самимилек бар иде аңарда.* Ә.Еники. *Әллә үз гадәте, самимилеге, садәлеге, рухи халәте шулаймы?* С.Поварисов

**САМИМИЯТ** *и. гар. кит. к.* **самимилек**. *Сәяси һәм икътисади сәбәпләр безнең гаммәбезне вак буржуа, бик вак буржуа гына ясап калдырган заманнан башлап, инде без җәмәгать эшләребездә чын самимият вә бер фидаилек белән эшләрлек гонсырсыз калып килә идек.* Ф.Әмирхан. *Шуның белән бергә андагы бу самимият табигыйлек белән дә башкалардан күп аерым тора.* Г.Сәгъди

**СА́ММИТ** *и. ингл.* Төрле дәүләт, хөкүмәт башлыкларының җыелып очрашуы һәм эшлекле сөйләшүләре. *Саммитта төрле илләрдән 150 ләп кеше катнашыр дип көтелә.* Ватаным Татарстан. *БДБ илләре саммиты. «Зур сигезлек» илләре саммиты*

**САМОВАР** *и. рус к.* **самавыр**. *Самоварга чыра салгансың да, күмер салмый чыгып киткәнсең, самоварың бөтенләй сүнеп беткән.* Ш.Мөхәммәдев

**САМОГОН** *и. рус* Иң гади ысул белән йорт шартларында әзерләнә торган исерткеч эчемлек; йорт аракысы, көмешкә. *Бу – самогон заманы иде, ул заманда аны «күмүшкә» диләр иде.*

Ә.Еники. *Таптың сүз: керосин! Самогон диләр моны, беләсең килсә!* Г.Ахунов

**САМОГОНЧЫ** *и.* Самогон ясаучы яки шуның белән сату итүче. *Мәсәлән, самогончыларга салына торган штрафлар кырыcландырылды.* Шәһри Казан. *Үз вакытында бу самогончылар хәтта бер-берсен «сату»га да барып җиткән, диделәр.* Ватаным Татарстан

**САМОДЕРЖА́ВИЕ** *и. рус* Элекке Россиядә патшаның чикләнмәгән хакимлегенә нигезләнгән дәүләт белән идарә итү системасы. *Рус самодержавиесенә һәм боярларына каршы ниндидер ачу, үчлек ята, минемчә, аның бу хәтәр-кыю хәрәкәтендә.* Ә.Еники. *Үткән гасырларда бу идеяне өч кит тәшкил иткәнне дә беләбез: самодержавие, православие, народность.* Р.Зәйдулла

**САМОЕД** *и. рус* Төньякта яшәүче ненецлар, селькуплар, нганасаннар һ.б.ш. кардәш халыкларның уртак исеме һәм шул халыкларның вәкиле. *Ләкин сөрген уставлары кешеләрне фикер хуҗаларына, мөхәррирләргә вә йирле самоедларга аермый.* Г.Исхакый. *Ул иштәкләр, вогуллар һәм самоедлар белән бик файдалы әйберләр алмаштырып сәүдә итүне юлга сала.* Гасырлар авазы. *Самоед телләре*

**САМОКАТ** *и. рус* Бер аяк белән җирдән этенүдән хәрәкәт итә торган рульле, утыргычсыз транспорт төре яки шундый уенчык. *Агачтан самокат ясап маташкан келәтеннән Минзай да йөгереп чыкты.* Г.Бәширов. *Юл борылышында ул самокатка атланган ике кешене куып җитте.* Ф.Шәфигуллин

**САМОЛЁТ** *и. рус* Хәрәкәтсез канатлары астына һава басымы бирү ярдәмендә күтәрелеп оча ала торган моторлы аппарат; очкыч. *Юлда ук алар утырган поездга немец самолётлары бомба ташлаган.* А.Гыйләҗев. *Самолёттан төтен чыга башлады, аннары ул, агач башларын сындыра-сындыра, бераз очты да җиргә кадалды.* Г.Әпсәләмов. *Рафаэль бу самолётны яхшы белә иде, аңарда ул бер генә тапкыр очмаган.* Р.Мөхәммәдиев

**САМСЫРА́У** *ф.* Бераз авырып китү, хәл китеп тору. *Ятьмә, кармакларына бернәрсә дә эләкмәсә, яисә чабак, каракойрык, ташбаш кебек вактөяк кенә эләккән чакларда, ул аруыннан самсыраган төс белән әкрен, авыр атлап, буш калай савытын аркасына асып, кешеләрне күрәсе килмәгәндәй як-ягына игътибар итмичә, күзләрен җиргә терәп, урман юлыннан авыл урамына уза да, үз чатына җиткәч, өенә кереп югала.* Л.-Х.Таналин

**Самсырап китү** Соңгы вакытта самсырау

**Самсырап тору** Бераз самсырау. *Бервакыт, әти өйдә юк, әни кергән: «Бер тәкә самсырап тора әле, әтиең дә өйдә юк ичмасам, пычтереп карар иде», – ди.* Ә.Минһаҗева

**САМУРАЙ** *и. яп.* 1) Феодаль Япониядә югары хәрби-феодаль катлау, өстенлекле каста вәкиле. *Ул яңадан Гоби чүлендә бер тамчы суга тилмереп, дошман белән сугышып йөрергә әзер, яңадан Хинган тауларында коеп яуган яңгыр астында тайгак үткелләрдә самурайлар белән бил алышырга әзер, тик поезд бары бер тәүлеккә генә Зөя буенда туктасын иде...* Х.Ширмән

2) XX гасырдан: гомумән япон хәрбие. *Кырык бишенче елның җәендә, самурайларга каршы сугышканда, берзаман чүлдә калдык.* Н.Әхмәдиев

**САМШИТ** *и. фар.* Самшитчалар семьялыгыннан көньякта үсә торган бик тыгыз һәм авыр үзагачлы кечкенә агач яки куак. *Иң каты агач – самшит, ул тимердән дә катырак.* Р.Нуруллин. *Самшит үзагачы гадәттән тыш каты һәм, әйберләр ясаганда, еш кына металлны алмаштыра ала.* Дөньяда ниләр бар?

**САМШИ́ТЧАЛАР** *и. күпл.* Икеөлешле үсемлекләрнең берничә мәңгеяшел төрне берләштергән бер семьялыгы

**САН** I *и.* 1) Предметларны санау, берәмлекләп барлау өчен кулланыла торган микъдар төшенчәсе, математик зурлык. *Дәфтәр битендә борынгыча болгап-чолгап язылган ниндидер язмалар, билгеләр, бик күп саннар күренгәләп калды.* Г.Бәширов. *[Лифтта] Фәрит, гасабиланып, биш саны сугылган төймәгә басты.* М.Кәбиров. *Башымны кисмәгә бирергә риза, үз формуласындагы ике-өч санны ул түшәмнән алгандыр.* А.Тимергалин

2) Саннар (*1 мәгъ.*) белән күрсәтелгән хисап, сводка һ.б.ш. мәгълүмат. *Зур күләмле союз булыр өчен, Барыннан да битәр сан кирәк.* Х.Туфан. *[Хәят:] Әни, сезне Зөләйха апа чакыра, бүгенге саннарны сорый.* Ә.Камал. *Әлеге саннарны тыныч кына тыңлап утырган журналистлар, беренче июльдән гамәлгә кергән үзгәрешләр турында сөйләшә башлагач, Рифкать Миңнехановка сорау яудыра башлады.* Ватаным Татарстан

3) Микъдар яки күләм. *Карале, умарталар саны ишәйгән, балы да шактый буладыр.* Г.Галиева. *Әйтик, Галәмдәге планеталар саны һәм, димәк, техник яктан өлгергән акыл ияләре арасындагы ераклык та төгәл билгеле түгел.* А.Тимергалин. *Җитмәсә, хуҗалыкларда мал-туарның баш саны кимегәч, саламнан күп нәрсә юк бит хәзер.* Шәһри Казан. *Халык санын алу*

4) Вакытлы матбугат басмаларында: номер. *Төрек укучысын татар әдәбияты белән таныштыру өчен, ул миннән китаплар, «Казан утлары», «Идел» журналы саннарын җибәреп торуны сорады.* Ә.Кәримуллин. *Бу газета-журналларда сан саен диярлек аның шигырьләре, мәкаләләре, фельетоннары, памфлетлары, пародияләре басылып тора.* Р.Башкуров

5) *лингв.* Предметның микъдарын, данә исәбен яки тәртибен белдергән сүз һәм шундый сүзләрне үз эченә алган сүз төркеме. *Төрле-төрле саннардан төзелгән парлы саннар да чама саны итеп карала: биш-алты, утыз-кырык.* Татар теле. *Микъдар саны. Тәртип саны. Бүлем саны. Җыю саны*

6) *лингв.* Предметның бер генә яки күп булуын белдерә торган грамматик категория. *Өйгә эш: «чиләк» сүзен ике төрле санда да төрләндереп, дәфтәргә язып килергә...* М.Мәһдиев. *Кызык. «Без» алмашлыгы күплек санны аңлата бугай, бөек вәкил.* Н.Гыйматдинова. *«Кадр» димәде, «кадрлар» диде. Ягъни мәсәлән, күплек санда.* Г.Сабитов

**САН** II *и.* Ихтирам, кадер; игътибар. *Сала кешесенә калада сан юк, дип*

*әйткән иде аны минем җәмәгать, ягъни җиңгәң...* А.Гыйләҗев. *Көне-төне сайрый сандугач. Сайрамый нишләсен, сан булгач.* Мөҗәһит. *Синдә малайлар күп булгач, кызларга сан юк инде... Ха-ха-ха!* А.Хәлим

◊ **Санга алу** *к.* **санга сугу**. *Разве байлар, безнең кебек кешеләрне санга алып, безнең белән сөйләшеп торалар!* М.Гафури. *Бик әшәке гадәт бу, бик! Искелек калдыгы, халыкны санга алмаудан килеп чыга.* Г.Бәширов. *Ул язмалар элек аерым көе йөргән, игътибарга, санга алынмаган.* В.Имамов. **Санга санау** *к.* **санга сугу**. *Шул югарыдагы хасиятләре аркасында инде аның кәкре аяклары бөтенләй санга да саналмый.* Г.Толымбай. *Әгәр ул Василий чыраенда санга санамау шикелле берәр нәрсәнең чаткысын гына сизеп калса да, перчаткасын салып тормастан, «мужикның» аяк астына берне кундырыр иде.* Ә.Еники. *[Гапсаттар:] Безне санга санап килүеңә бик рәхмәт инде, Зиннәтулла.* Ю.Әминов. **Санга сугу** Игътибарга алу, исәпләшү, санлау, хөрмәт итү. *Мине санга сукмаганга, шаяртып маташасыз.* А.Гыйләҗев. *Исемдә басым да беренче иҗеккә төшә, тик татар урыс теле законнарын санга сугамыни ул?* Р.Зәйдулла. *Юкмыни соң синең берәр Эш күрсәткән улкаең? Санга да сукмыйлар сине, И мескен авылкаем.* Мөҗәһит. **Санга тыгу** *к.* **санга сугу** (кешеләр турында гына). *Хәзер безне шул өч тиен тормый торган балыкчылар да санга тыкмый, нинди хурлыкка калдык, дип пыскыдылар [алар].* Г.Толымбай

**САН** III *и.* Гәүдәнең берәр өлеше. *Көне буе ат өстендә килгән алып ир бик нык ачыккан иде: күз ачып йомганчы, ул сарыкның бер як санын ялт иттереп куйды.* Н.Фәттах. *Ат өркеп ал санын күтәрде һәм ачы тавыш белән кешнәп җибәрде.* М.Мәһдиев // *сөйл.* Гомумән гәүдә. *Хәлимнең Кафияне култыклап алырга кыюлыгы җитмәс иде. Ә Кафия сорап тормады, култыклады, саны белән Хәлимгә орынып-орынып бара.* И.Гази. *Ул санын күтәреп тора алмаслык дәрәҗәдә арганлыгын тойды.* Х.Камалов. *Иптәшләренең, яшьтәшләренең яуга китүен, үзенең гарип санын саклап калуын йөрәге күтәрә алмаган икән бичараның...* А.Гыйләҗев

**САН-** Кушма сүзләрдә «санитария», «санитариягә мөнәсәбәтле» мәгънәсендәге беренче кисәк, мәс., *сантехник, сандружина, санэпидстанция, санпост, санбат, санрота, санпоезд*

**САНА** *кис., боерык фигыльләргә кушылып языла* 1) Үтенүне белдергән фигыльгә ялыну төсмере өсти. *Күшеккән күңелем җылынсын – Колларым учыңа алсана! Күшеккән күңелем җылынсын – Җанымны учыңа салсана!* Ш.Җиһангирова. *Ай Аллам! Чытырдамасана, яшен!* Н.Гыйматдинова. *Карасана, онытмаган икән Мөхәттәрә дә...* Р.Йосыпова. *Купшы утырып креслосына Мияугали, Мыекларын ялый-ялый, Мал врачы Ябалакка шалтырата: – Тыңлагызсана, зинһар, Сезгә бик зур йомышым бар ---.* Г.Шамуков

2) Кирәксенмәү, санламау, ирония кебек төсмерләрне белдерә. *[Хәсән хуҗа кызы турында:] Кайтмаса, хәерле булсынсана!* Ф.Әмирхан. *[Гайшә Шакирга:] Әй, кыланмасана.* Ф.Бурнаш

**САНАГЫЧ** *и.* 1) Төрле озынлыкта һәм төстә ясалып, санарга өйрәтүдә кулланыла торган кечкенә таяклар. *Иген тутырылган капчык сыман кыска буйлы, билсез укытучы Кәримә апалары, өстәле артыннан чак-чак күренеп, аларга өйгә эш бирде: ун таякчыктан торган санагыч ясарга.* А.Хәлим

2) Нәрсәне дә булса санап бара торган әсбап, җайланма. *Адымнарны санагыч сатып алдым.* Ш.Галиев. *Газ санагычы. Электрон санагыч*

**САНАЙ** *и. диал.* Җәя. *Өнәндә үтте ун батыр, Ун батырдан иң батыр Санае күк соландай, Тартып атса санаен Күктә йолдыз югалткан, Күк батыр дип аталган – Аны күргән картыңмын.* Дастан

**САНАЛМЫШ** *и. лингв.* Сан сүз төркеме тарафыннан ачыклана торган сүз. *Башка төркемчәләрдән үзгә буларак, җыю санының саналмышы булмый (бишәү укучы, өчәү кеше дип әйтелми).* Татар теле. *Саналмышның җөмләдә ия яки тәмамлык булып килүе*

**САНАМЫШ** *и.* Уенда катнашучыларның урыннарын билгеләгәндә, вәзен белән әйтелә торган кыска гына шигъри тезмә. *Уенчыларны бүлүдән башлаган санамышлары да урысча булганлыктан, уенга хәрәм кертә дип, үзебез дә аңа санатмый башладык.* Н.Гариф. *Һәр ана баласына, «тел ачкычы» бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уен оештырган, әкиятләр укыган, үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән.* Шәһри Казан

**САНАТ** *и. лат. иск.* 1) *к.* **сенат** (*2 мәгъ.*). *Әбүбәкер солдат булмаса, кем бу татар җәмгыятенең сүзен санат хәтле санатка үткәзерлек итеп язар да, кем аны шундый югары урынга җиткерергә алыныр иде?* М.Рафиков

2) *к.* **сенатор**. *Мең санат, мең солдат, Һәр солдатта мең канат. (Урман)* Табышмак. *Кызлар алар яшь чагындарак, патшага барам мин, дип торалар да, ди, аннан ары, санатка, дип әйтәләр, ди, ул да эләкмәгәч, актыгында, солдат булса да ярар, дип әйтәләр, ди.* Г.Камал

**САНАТО́РИЙ** *и. лат.* Дәвалану, авыруларны кисәтү һәм ял итү йорты. *Докторлар санаторийга барып дәваланырга киңәш иттеләр.* И.Салахов. *«Хатынын ике айга көньякка санаторийга җибәрә дип, Идристән көләдер әле бу тел бистәсе!» – дип уйлады ул эченнән генә.* А.Гыйләҗев. *Хәбибрахман исә Кырымнан миңа нинди санаторийда эшли башлавын язган иде инде.* Ә.Еники

**САНА́У** I *ф.* 1) Саннарны үз тәртипләре белән бер-бер артлы әйтеп бару. *Ике тапкыр унга тикле санарлык вакыт узуга, дарулар баскыч төбенә килеп утырды.* А.Тимергалин. *Мин зур инде, укыйм-язам, Унга кадәр саный беләм. Күбрәк тә санар идем, Туктыйм унбер саны белән.* Г.Гыйльманов

2) Нәрсәләрнеңдер төгәл ничә яки күпме икәнен билгеләү. *Төлке төшендә дә тавык саный.* Мәкаль. *Саный сәгать... Ләкин аңламый ул Безнең ничек алга барганны.* Х.Туфан. *Көяз түрә бармагы белән һәрберебезнең күкрәгенә төртеп санады: сәкегә чыгарды.* И.Салахов

3) Кем яки нәрсәдер турында нинди дә булса фикердә булу; исәпләү, уйлау. *Менә сез мине инде юләргә саныйсыз.* М.Мәһдиев. *Миңа игелек кылучыларның берсен дә, син әйткәнчә, чит кешеләр дип санамыйм, туганнарым ук булмасалар да.* Г.Галиева. *Иң мөһиме: Сәфәргалиев үзен татар санаган, гомере буе татар тарихын төрле ялганнардан араларга теләп яшәгән...* Р.Зәйдулла

**Санап алу** Тиз арада санау. *Май аенда урманга керүнең ни яме бар, әгәр анда вакыт-вакыт күке, кычкырып, синең гомереңне санап алмаса?* М.Мәһдиев

**Санап бару** Берсен дә калдырмыйча, рәттән барысын да санау. *Нәҗип дәшмәде, күңеленнән генә кемнәргә күпме бурычы булуын санап барды.* А.Гыйләҗев

**Санап бетерү** Бөтенесен да санау. *Димәк, мин һәм минем иптәшләрем бала тәрбияләгәндә бернинди хисап машинасы да санап бетермәслек энергияләрен, йөрәк майларын, күз нурларын заяга исраф итмиләр...* Ф.Әһлиуллина. *Акттагы имзаларны, титулларны хөрмәт белән санап бетергәннән соң, үзенең дә шул акт белән теләктәшлеген белдерергә ашыккан сыман сөйләп тә китте [Ниса Чәймилова].* А.Гыйләҗев

**Санап йөрү** Һәрвакыт, гел санау. *Шулай дияренә ышанып чабам, чөнки мин үземне талантлы санап йөрим, үз чордашларымнан гына түгел, өлкәнрәкләрдән дә шәбрәк яза алам, дип ышана идем.* А.Гыйләҗев. *Үзен әллә кемгә санап йөрмәсен бүтән.* Г.Тархан. *Ә ул, менә бит ничек, үзен өстеннәрдән санап йөргән икән.* Ф.Яхин

**Санап тору** Регуляр төстә санау; хәзер санау белән мәшгуль булу

**Санап чыгу** Башыннан ахырына кадәр бөтенесен санау. *Ул [Ниса Чәймилова] ашыкмыйча, иренмичә, бутамыйча, Әхәтнең ничә тапкыр эшкә соңарып килүен, эш вакытында ничә минут югалып торуын, буфетта ничә шешә сыра эчүен берәмтекләп санап чыкты.* А.Гыйләҗев. *Мин барлык катнашучыларны санап чыга алмыйм.* А.Расих

**Саный башлау** Санарга тотыну. *Әнвәре белән Миләүшәсе исенә төшкәч, үзен дөньядагы иң намуссыз кеше итеп саный башлый иде.* Г.Ахунов. *Әби калтыраган куллары белән акчаларны саный башлады...* Г.Гыйльманов. *Сөмбелнең башына суккандай булды, күңеленнән көннәрне саный башлады.* З.Кадыйрова

**Саный китү** Рәттән санау. *Авылга кайткач, монда төрле каршылыклар: төртмә сүзләр, никахны яңарту кирәклеге үзе генә дә күпме айкады аның күңелен, күз яшьләрен түгеп, ялгыз үткән төннәре, Нургалиенә карата да шик-шөбһәләр – саный китсәң күп инде алар.* Г.Галиева. *Саный китсәң – бармаклар җитмәс, уйлый башласаң – дивана булырсың...* Ф.Шәфигуллин

**Саный тору** Әлегәчә санау

**САНА́У** II *и.* Исәпләү, санау процессы яки нәтиҗәсе. *Кемгә әле утыз, кемгә инде сиксән – Үзгәрми ул санаулардан бернәрсә дә, Аккан суга керәләр тик бер мәртәбә!* Д.Гыйсметдин

**САНАУЛЫ** *с.* 1) Саналган; саны билгеле. *Бүре санаулы сарыкны да ашый.* Мәкаль. *Санаулы көннәр тиз үтеп китте. Яшьләрнең шәһәргә кайтыр көннәре якынлашты.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Бик аз. *Дөрескә чыкса, карт соңгы санаулы көннәрен яши.* А.Гыйләҗев. *Калган санаулы көннәр искән җил кебек үтеп тә киттеләр.* Г.Галиева. *Ялгыз арыслан күрсәгез, белеп торыгыз: ул көтүдән куылган, һәм аның көннәре санаулы...* Р.Зәйдулла. *Болай да санаулы гына кунакларның вак төркемнәргә тарала баруын күреп, ул үзе үк җыр башлап карады.* Р.Мөхәммәдиев

**САНАУСЫЗ** *с.* 1) Саналмаган; саны билгесез. *Санаусыз акчасы булмас, нәрсә эшләр икән: белер микән, белмәс микән диеп сынавым гына иде сине, кара чуен...* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Чиксез күп. *Бабай, син байларның санаусыз маллары бар дип беләсеңме әллә?* М.Гафури. *Үз маллары кырда йөри караусыз, Игенчегә зыян сала санаусыз.* Һ.Салихов. *Җир хуҗалары, су хуҗалары... Хәер, алар бүген санаусыз.* Н.Гыйматдинова

**САНАУЧЫ** *и.* 1) Санау (I) хезмәтен башкаручы, шундый эштә эшләүче. *Җыелышта тавыш бирүчеләрне исәпкә алу өчен санаучылар билгеләү*

2) *мат.* Вакланманың бүленә торган өлеше. *– Яз әле, сеңелем! – Гамир тавышында килешле бер вәкарь сизелде. – Икс тигез... нәкъ уртага озын сызык сыз. Санаучыда – минус «в» квадрат...* Р.Ишморатова

**САНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *мед.* Авыруны вакытында кисәтү һәм дәвалану максаты белән әледән-әле табибка йөреп тикшерену. *Авыз куышлыгы санациясе*

2) *тех.* Сүүткәргечләр һ.б.ш.ны төзәтү һәм чистарту технологиясе. *Торбалар санациясе*

**САНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Санация ясау, санация үткәрү

**САНАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **санау** (*1, 2 мәгъ.*).

2) Кем яки нәрсәнедер исәпкә, игътибарга алу, шуның белән исәпләшү; санлашу. *Наиләнең үз йортындагы мәшәкатьләре белән генә мавыкмавы, ни кушсаң, шуны үтәве, вакыт белән санашмавы колхоз өчен сатып алалмаслык табыш иде.* К.Тимбикова. *Картаю – кешенең абруе төшә бару, аның белән санашмый башлыйлар.* Ш.Галиев. *Бөркет кебек оч син югарыда, Санашсыннар синең белән дә.* Ф.Зыялы

**Санаша башлау** Билгеле моменттан алып санашу

**Санаша тору** Билгеле моментка кадәр санашу

**Санашып тору** Гел, даимән, хәзерге вакытта санашу

**САНӘМ** *и. гар.* Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал, пот. *Моны күреп, Йосыф сәүче дога кылды, Санәм авып төште дә ун кисәк булды, Шул чак санәмгә Тәңредән әмер килде, Санәм: «Йосыф – хак пәйгамбәр!» – диде имди.* Кол Гали. *Шәүләсе алдында баскан нәкъ илаһи бер санәм, Шул сурәт алдында табынып шатланам, ләззәт алам.* М.Гафури. *Зур санәмнең аузына Ниндидер ят кап-кара җаннарны Ыргый, ташлыйлар... Ташлыйлар, ул зур санәмнән Мәңгелек бәйрәм теләп.* Һ.Такташ

**САНВРАЧ** *и. рус* Санитария табибы. *Лоскутов дигән санврачны Булавина*

*югында баш итеп билгеләгәннәр иде.* А.Гыйләҗев

**САНГВИ́НИК** *с. лат.* **1.** Шат күңелле, уйнак, тере, хискә тиз бирелеп, тирәнгә китмичә тиз суынучан (темперамент, холык тур.)

**2.** *и. мәгъ.* Сангвиник темпераментлы кеше. *Юк, алай түгел, иң авыры, психология. Аты коргыры фән! Меланхолик, сангвиник, холерик, флегматик, имеш.* М.Мәһдиев

**САНГИ́НА** *и. лат.* 1) Рәсем сәнгатендә кулланыла торган куе кызыл яки кызгылт көрән төсле сапсыз йомшак карандаш. *Сангина белән ясалган рәсем*

2) Шул карандаш белән ясалган рәсем үзе

**САНДАЛ** I *и. гр.* Сай эчле, аркылы эләктергечле, үкчәсез җәйге кун аяк киеме. *Коридор тулы бала... Кайсының сәдәфе төшкән, кайсының сандал бавы өзелгән, кайсының маңкасы аккан...* М.Маликова. *– Фи, – диде кызчыкның әнисе, кызыл тырнаклары белән курчакның сандалларына чирткәләп караганнан соң.* Ф.Шәфигуллин

**САНДАЛ** II *и. фар.* Эшләнмәне куеп чүки торган махсус авыр тимер аслык. *Әмма соң Саша Гаврилов оста сөйли, каһәр. Корыч сандалга чүкеч кыйнаган шикелле чыңлата да тора.* Ш.Камал. *Адәм баласы сандалдагы тимер түгел, чүкеп, я әшәке, я әйбәт итеп ясап булмый.* А.Гыйләҗев. *Заманалар чуен сандалларда Чүкегәндә безнең кавемне, Эндәшмичә һаман түзә килдек, Учыбызда тотып бәгырьне.* М.Сафиуллин

**САНДАЛ** III *и. гар.* 1) Сандалчалар семьялыгыннан җылы якларда үсә торган хуш исле, эфир майларына бай мәңгеяшел агач. *Япониядән алып Испаниягә кадәр ул [Гайшә Хәлиловна] булмаган ил юк, Һиндстанда ике мәртәбә булды, сандал агачыннан ясалган филен үземнең дә иснәп караганым бар.* А.Гыйләҗев. *Шәрык илләрендә әле дә кунакханәләрдә искә зур игътибар бирәләр: сандал агачы исе, арахис исе һ.б. затлы исләр чыгарып бүлмә әзерләү кунакка ихтирам билгесе булып санала.* М.Мәһдиев

2) Шушы һәм бүтән кайбер агачлардан алына торган табигый буяу. *Сандалга буяу*

**САНДАЛИ** *и. гр. к.* **сандал** I. *Әннәгигеннәгә, Аягымда сандали. Сандали түгел пима, Яшь күңелемне тыйма.* Җыр. *Улым уянган, сандалиларын күтәреп килгән дә, «наннали, наннали» дип лепелдәп, мине тагын урамга йөрергә чакыра.* А.Гыйләҗев. *Өстенә изүе ачык киндер күлмәк, тезләре кырык кат ямалган малюскин чалбар, чебиле аякларына нимес балалары аягыннан күчкән, табаннары тапталып беткән иске трофей сандали эләктереп алган Сәгъдәт җай гына урам аша чыкты.* А.Хәлим

**САНДА́Л СӨЯК** *и. анат.* Урта колактагы кечкенә сөяк

**САНДА́ЛЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Вак чәчәкле, ике җенесле куаклар, агачлар һәм күпьеллык, сирәгрәк берьеллык үләннәрне берләштерә торган семьялык

**САНДАРАК** *и. гр. бот.* Африкада үскән ылыслы агач кайрысыннан алына һәм лаклар әзерләүдә кулланыла торган хуш исле сумала

**СА́НДВИЧ** *и. ингл.* Ике телем икмәк арасына йомырка, колбаса, ит һ.б.ш. куеп әзерләнгән ашамлык

**САНДУГА́Ч** *и.* **1.** 1) *зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан коңгырт яки соргылт төсле, нәфис тавышлы күчмә сайрар кош. *Ә инде хикәя, повесть, романнар язган кешегә, барын да күрү өчен – бөркет күзе, ишетү өчен – ябалак колагы, күргән-ишеткәнне кәгазьгә сәнгатьчә төшерү өчен сандугач теле кирәк.* С.Поварисов. *Шофёр Зөфәр исә каяндыр сандугач тотып алып кайтты.* Р.Сәлим

2) *күч.* **сандугачым** *тартым форм.* Иркәләп эндәшү сүзе. *«Ир хакы – тәңре хакы» дигәнне күп әйтәсең, сандугачым, ә менә хатын хакы нindирәк икән ир өчен?* С.Поварисов. *– И акыллым, матурым, сандугачым, күз нурым, – ди Гөлсем ханым балага, – пилмән ул – бик тәмле ризык.* Р.Батулла. *Бер минут истән чыкмыйсың, сандугачым...* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ. күч.* Бик күркәм, нәфис, музыкаль (тавыш һ.б.ш. тур.). *Сине түгел, әнә сандугач телле Касыймны да세берке белән куып чыгарган.* Ф.Абдуллин. *Чөнки бу ханым – гүзәллеге вә күңелләрне үзенә тарту көче белән һәркемне кол итәрлек сандугач тавышлы шул.* Ф.Яхин

**САНДУГА́Ч ТӘПИЕ** *и. бот.* Күгәрчен тәпие, канәфер чәчәк. *Әгәр июль башында узсаң, барыбер безнең бакчага кер: чәчәк диңгезен күрерсең, анда алабай чәчәге, алма үләне, сандугач тәпие, баллы куәт гөрләп утыра.* М.Мәһдиев

**СА́НДХИ** *и. санск. лингв.* Ике морфема яки ике сүз арасындагы авазларда була торган аваз үзгәрешләре (*эшлә әле – эшләле, бара иде – барайде*). *Сузыкка беткән сүздән соң сузыкка башлана торган сүз килсә, ул сузыкларның берсе төшеп кала (сандхи).* Мәйдан

**САНДЫК** *и. гар.* Әйберләр саклау өчен хезмәт итә һәм күгәнгә утыртылган капкачы гадәттә бикләнеп куела торган зур тартма. *Бишекне өстән үк урап ябып куя торган юка каплавычын сандыгыннан эзләп тапты: хәсиятленең хәсиятле инде.* Г.Галиева. *Сандык калын имән такталардан ясалган, сум тимердән ике коршау белән уратылган, зур йозакка бикләнгән була.* Р.Зәйдулла

**САНДЫК-СОНДЫК** *җый. и.* Төрле зурлыктагы, эреле-ваклы сандыклар. *Текә баскычта авыр-авыр төеннәр, сандык-сондык күтәргән ирләр, хатын-кыз күренде.* А.Гыйләҗев

**САНДЫКЧА** *и.* Кечкенә сандык, кумта. *Грун, бер иркен вакыт табып, хәзинәгә керде. Анда теге сандыкчаны эзләп тапты да карады. Күрде: сандыкчада бер матур кызның сурәте ята.* Ф.Халиди

**САНДЫКЧЫ** *и.* 1) Сандык ясау остасы

2) Сандык белән сәүдә итүче

**САНҖАК** *и.* 1) Байрак, әләм

2) Госманлы Төркиядә вилаятьтән кечерәк, казыйлыктан зуррак административ берәмлек; губерна. *Санҗак бәе*

**САНИТАР** I *и. лат.* Авыруларны һәм яралыларны карау, дәвалау йортын җыештыру кебек эшләрне башкаручы кече медицина хезмәткәре. *Уфылдап куя санитар, Йөрәген тыңлап аның. Бирмәскә тели бу йөрәк Үлемгә солдат җанын.* Х.Туфан. *– Кем сызгырта? – дип гаҗәпләнеп сорады санитар.* Г.Мөхәмммәтшин. *Авырулар-*

*га мөнәсәбәтегез, гади санитарлар белән ничек сөйләшүегез, холкыгыз, гадәтләрегез турында мин күп нәрсә әйтә алыр идем.* А.Тимергалин

**САНИТАР** II *с. лат.* Санитариядә файдаланыла торган. *Нур Фатыйхович, «Тын күл» дачасының санитар-биологик таләпләргә җавап бирмәвен яздан ук кисәтмәдекмени?* А.Гыйләҗев. *Кичкә таба Җидегәннең ындыр артына Бөгелмәдән санитар самолёты килеп төште.* Г.Бәширов. *Беренче станциядә үк аларга санитар поезды очрады.* Ф.Әһлиуллина

**САНИТАРИ́Я** *и. лат.* Сәламәтлек саклау системасының гомуми чисталык һәм гигиена кагыйдәләре үтәлүен күзәтү чаралары. *Чынлап та Әминә һич тынгылык белмәде: мәктәптәге санитария кагыйдәләре белән танышып чыкты...* Г.Минский. *Санитария юк, су юк.* З.Зәйнуллин

**САНИТА́РКА** *и. рус* Хатын-кыз санитар (I). *[Әскәр Моратов] Лизурканың урам аркылы гына поликлиникада санитарка булып эшләвен белде.* А.Гыйләҗев. *Менә Зәмзәмияне дә эшкә тартырбыз. Санитарка була алмас идемени?* Г.Минский. – *Ун минуттан барлык санитаркаларны минем бүлмәгә җыегыз! – дип чыгып китте [мөдир].* Р.Ишморатова

**САНИТАРЛЫК** *и.* Санитар (I) хезмәте һәм вазифасы. *[Ирекле булып фронтка китәргә теләүчеләр:] Безне стройга алыгыз. Санитарлыкка бездән картраклар да табылыр әле.* Ш.Усманов

**СА́Н ИТҮ** *ф.* Хөрмәт күрсәтү, санлау. *Совет властен сан итүем турында шулай ук анык әйттем.* М.Хуҗин

**СА́НКИ** *фар. терк. иск. кит.* Гүя, гүяки, әйтерсең. *Ялтырыйдыр санки нурдан бер балык, – Бер фәрештә күңледәй пакьтер кулың.* Г.Тукай. *Иске чапан белән керле чалма күргәндә күз чиркәнә, күңел имәнә, санки үлек белән каберлек күргән кебек буласың!* Дәрдемәнд. *Әй туган ил! Күп газаплар чиксәм дә синдә, син матур; Кайвакыт күрдем иләмле көннәреңне, санки нур.* Г.Сөнгати

**СА́НКЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Югары инстанциядән бирелгән рәсми рөхсәт, ризалык. *Прокурор санкциясе кирәк булу*

2) Халыкара хокукый нигезләргә таянып, килешүне бозган якка каршы кулланыла торган чара. *Ниндидер санкцияләр кертелгән очракта да, техника һәм азык-төлекне башка илләрдән сатып алырга була.* Ватаным Татарстан

3) Рәсми-административ тәэсир итү чарасы. *Административ хокук бозулар буенча РФ Кодексының «Урам чараларын үткәрү» турындагы маддәсе шактый кырысландырылды, үтә зур суммадагы штраф санкцияләре гамәлгә кертелде.* Безнең гәҗит

**СА́НКЦИЯЛӘҮ** *ф. кит.* Рәсми рөхсәт, ризалык, санкция бирү (югары инстанцияләр тур.). – *Бу – санкцияләнмәгән митинг, закон бозып йөрмәгез, өегезгә кайтып, җылы чәй эчегез дә одеял астында ятыгыз, – диде ул хезмәткәр киң елмаеп.* Безнең гәҗит

**СА́НКЦИЯСЕЗ** *с.* **1.** Рәсми рәвештә рөхсәт ителмәгән. *Гомумән, полиция килеп, санкциясез җыен дигән булып акыл сатып йөрмәде.* Безнең гәҗит. *Хәтта мэр, мәчет өчен җир бүлеп бирелгән урында җыелыш ясасагыз, ОМОН җибәреп, санкциясез митинг оештыралар, дип кудыртам, диеп куркытып маташты.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Рәсми рөхсәтсез, рәсми рөхсәт булмый торып. *Митинг санкциясез оештырылган*

**САНЛА́У** I *ф.* 1) Игътибарга, исәпкә алу, санга сугу, хөрмәт итү; тыңлау. *Санламадылар инде аталарын, үлгәнен генә көтәләр, миһербансызлар.* Н.Гыйматдинова. *Инде хат яза-яза арып беткәннәрдер, аларны да бераз санларга кирәк иде – тәки ризалатты бит.* М.Шабай. *Әтәч әйткәнне аңламый, Әллә безне санламый...* Мөҗәһит

2) Карышмау, тыңлау (хайван тур.). *Яз дәрте белән җиңеләйгән атлар кызларны санламыйча боргалана һәм киреләнәләр.* Г.Бәширов

**Санлап бетерү** Тиешенчә санлау. *Фермага үзең кайтмый ярамас. Ул [айгыр] мине генә санлап бетерми.* Ә.Камал. *Элегрәк спортны санлап бетермәүчеләр шактый иде.* Ватаным Татарстан

**Санлап тору** Гел, һәрвакыт санлау. *Бездә кешеләрне санлап тормыйлар.* Безнең гәҗит. *Казна эшендә мин дә чиләнәм, дип хокук дауламый, мине санлап тора, өс киемнәремне юып кигезә, ашарыма әзерли, балаларны карый, дигәннәре ничектер хәтергә уелып калган.* Татарстан яшьләре

**Санлый башлау** Санларга тотыну. – *Менә шунда Россияне чит илләр дә санлый башлаячак, – дип ышаныч белдерә Мишарин.* Ватаным Татарстан

**САНЛА́У** II *и.* Ихтирам, хөрмәт, олылау. *Ул аның ике арадагы – бәк белән осталар арасындагы – сүзне бүлдерүен һәм шуның белән сөйләшү йоласын санламавын бик яхшы аңлады.* Н.Фәттах

**САНЛАШУ** *ф. сөйл.* Берәүнең сүзен яки нәрсәнедер игътибарга алып, шуның белән исәпләшү. *[Хатны] шунда ук ачып укый башларга яхшысынмадым: мине сыйлыйсы килеп көтеп утырган командир белән, ничектер, санлашмау булыр иде.* Ә.Еники. *Матбугатка игътибар көчле иде, безнең белән санлашалар иде, диясем килә.* Ватаным Татарстан

**Санлаша башлау** Билгеле моменттан алып санлашу

**Санлашып тору** Гел, һәрвакыт санлашу. *Без, татарлар, сәяси көч буларак Россиядә үзебезне күрсәтә алмадык, шуңа күрә безнең белән санлашып та тормыйлар.* Ф.Бәйрәмова. *Аттың – бетте дә китте бит инде югыйсә, санлашып та торасы түгел.* Ф.Яхин

**САНЛЫ** I *с.* Сан яки саннар белән белдерелә, күрсәтелә торган. *Барысы да санлы форматка күчерелеп, институтның алтын фонды буларак дөнья күрәчәк.* Ватаным Татарстан. *Санлы һәм хәрефле дәрәҗә күрсәткечләре. Санлы күрсәткечләр*

**САНЛЫ** II *с.* Хөрмәтле, абруйлы. *Минем халкым бөек булса, Димәк, мин – санлы кеше.* Ә.Ерикәй. – *Менә шул-шул, – диде карт, – кайда гына карама – башсызлык, кайда карама – башбаштаклык, санлыга сан юк, сансызга юл юк.* Ш.Камал

**САНСКРИТ** *и. санск.* Борынгы Һиндстанның дин һәм әдәбият теле. *Туран, рун, уйгур язуларыннан тыш, борынгы төркиләр теге яки бу дәрәҗәдә санскрит, пәһләви, яһүди, латин*

*графикаларын да кулланган.* Х.Миңнегулов. *Санскрит язмалары*

**САНСЫЗ** I *с.* Чиксез күп. *Шәһре Сарай астында, Айдаланың башында Сансыз татар – кара яу.* Дастан. *Яланаяк килгән идек җиргә, Сукмаклары сансыз җиһанга.* Х.Туфан. *Соңрак сүз тараталар: имеш, Дәүләтхан теге урыс тартмасыннан сансыз акча таппкан...* Р.Камал

**САНСЫЗ** II *с.* 1) Тыңлаусыз, тәртипсез. *И Аллам, бигрәк сансыз нәмәстә булып чыкты ла бу Гөлсем.* Г.Гобәй. *Колагын борам әле мин ул сансыз малайның...* Г.Бәширов // Юньсез, начар. *[Сыерларның] Бер сансызы шунда гына бәвел чарылдата...* А.Гыйләҗев. *Хәзер мин үземне Изаелның акчасына ярамаган әйбер сатып алган бер надан сансыз кыз сыман хис итәм...* Р.Гаязетдин. *Кабан, агачка сырт ышкый-ышкый, имән төбендә иснәнә иде, тынычлыгын бозып, мылтыктан шартлаткан, җитмәсә өстенә лапылдап төшеп җен ачуын кабарткан сансыз адәмнең ботыннан умырып тешләде.* Н.Гыйматдинова

2) Абруйсыз, хөрмәтсез; кадерсез, кирәксез. *Сан ягыннан байтак булсак та без, Сансыз халык идек Рәсәйдә.* Х.Туфан. *Без бик сансыз кешеләргә әйләндек, җәмәгать.* Мәдәни җомга

**САНСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Сансызга, тыңлаусызга әйләнү. *Әллә холкының йомшаклыгы аркасында башта әнисе сүзеннән чыкмый яшәгән, ә аннары сансызланып аракы колына әверелгән, бердәнбер улын тормыш карамагына һәм әлеге дә баягы Фәния әбисе кулына калдырган әтисеме?* Безнең гәҗит

2) Сансызлык күрсәтү. *Кирәгеннән артык сансызлана торган яшь «абый»ның бөтен эшне бозып куюы бар.* Н.Фәттах.

**Сансызлана башлау** Сансызлануга табан үзгәрү

**Сансызланып китү** Билгеле моменттан башлап сансызлану

**Сансызланып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер сансызлану. *Беренче очраган белән монда... сансызланып торырга...* Идел

**САНСЫЗЛЫК** *и.* Сансыз булу. *– Ничегрәккә китә мондыен сансызлык? Ә?! – диде агай, урыныннан кубып.* А.Гыйләҗев. *Кызыңның бу сансызлыгы кодалар алдында безне дә оятлы итә дип борчыласы урынга...* Г.Галиева

**САНСЫНУ** *ф.* Санлау, хөрмәт итү. *Туры җирән башта, Габдулланы сансынмый, ялкау гына китте һәм, йөртүчесеннән көлгән сыман, күзләрен Габдулла ягына әйләндергәләп һәм колакларын алмаш-тилмәш яткызгалап барды.* Ә.Фәйзи. *Карт арысланга якын ук килергә шүрләсәләр дә сансынмыйлар, сансынмыйлар...* Д.Булатова

**САНТЕ́ХНИК** *и. рус* Санитар-техник җиһазлардан файдалану яки аларны монтажлау, ремонтлау эшләре белән шөгыльләнүче эшче. *Казанга урнашкач та әллә кем түгел, диделәр. Сантехник булып эшләгәнме шунда.* Р.Зәйдулла. *Шуннан соң инде базга төшеп йөргән кешене, Мәмдүдә карчыкның сантехник булып эшләүче улы түгелме икән, дип фараз иттеләр.* А.Тимергалин

**САНТИМ** *и. лат.* Кайбер илләрдә франкның йөздән бер өлешенә тигез вак акча

**САНТИМЕТР** *и. лат.-гр.* Метрның йөздән бер өлешенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Аның маңгай агыннан өстәрәк тәңгәлдә баш сөяге җимерелгән була. Сигез сантиметрга сигез сантиметр.* А.Хәлим. *[Хөсәенов] Җиргә иелде дә сөрү тирәнлеген кулы белән үлчәп карады. 10–12 сантиметр чамасы.* Р.Йосыпова. *Һәр сантиметр аны куйган максатына якынайта.* А.Тимергалин

**САНТИМЕ́ТРЛАП** *рәв.* 1) Сантиметр исәбе белән үлчәп

2) Сантиметрга кадәр төгәллек белән. *Биредә һәр нәрсә үз урынында, сантиметрлап сызгандай төгәл, пөхтә.* Татарстан яшьләре

3) Билгеле сантиметр чамасында. *Кыскасы, бу эксперимент белән мин шуны үлчәдем: сәрхушлыкка бер адым да юк, ара сантиметрлап үлчәнәдер, ә менә сукбайлыктан...* Безнең гәҗит. *Шул көннән алып, ул тәүлегенә 5–6 сантиметрлап минем өемә якынлаша.* Туган як. *Ә Ерак Көнчыгышта яшәүчеләр өчен бу, киресенчә, уңай һәм куанычлы күрсәткеч, чөнки бу очракта ул су баскан районнардан суның азазлап – сантиметрлап чигенүен аңлата.* Шәһри Казан

**САНТИМЕ́ТРЛАУ** *ф.* 1) Сантиметрлы бүлемнәргә бүлү. *Ул, сөрү катламын үлчәү өчен сантиметрлап ясалган үлчәү таягын Гайҗан агайдан сорап алып, --- сөрелгән мәйданның өстенә кереп китте.* Ф.Хөсни

2) Сантиметрга кадәр төгәллек белән үлчәү

**Сантиметрлап тору** Сантиметрлау белән шөгыльләнү

**САНТИМЕ́ТРЛЫ** *с.* 1) Сантиметрлар белән үлчәнә торган. *Димәк, 21 сантиметрлы спектр диапазонында башка төрле модуляцияләрне тикшерергә кирәк.* А.Тимергалин

2) Сантиметрларга бүленгән, сантиметр озынлыгындагы бүлемнәрдән торган. *Кулына утыз сантиметрлы пластмасс линейка тотып, ул да уйга чумган иде.* Ә.Сафиуллин

**САНТЫЙ** *с.* Юньсез, ахмак; уйламыйча эш итүчән, җиңел акыллы. *Латыйпларның сантый килене самавырын соскыга каккан да көлен, утыние белән, лапастагы кабык колашага түккән икән.* А.Гыйләҗев. *Өч йөз алтмыш йортлы Зартугайда бүтән беркем эчми: синең бөкрең эчә дә, минем сантыем эчә.* Г.Ахунов. *Шуннан соң инде без, ике сантый, алдыбызга китереп куйган сыйларны, кызарынып, сүзсез генә ашарга утырабыз.* Ә.Еники

**САНТЫЙЛАНУ** *ф.* 1) Сантыйга әйләнү. *Эшсезлектән, дүрт стенага карап өйдә утырудан тәмам арыган, үзен-үзе тыеп кил-килә сантыйланыр чиккә җиткән иде Фәзилә.* Г.Мирһади. *Хәмер дигәнең акылга камил кешене дә сантыйландыра.* Безнең гәҗит

2) Сантый булып кылану; сантыйлык эшләү. *[Әтисе – кызына:] Эшең бер дә юкмыни соң синең, бала-чага кебек аяк арасында сантыйланып йөрмәсәң.* Ф.Хөсни. *Ә без, сантыйланып, учакның уртасына ук барып кергәнбез икән бит.* В.Имамов

**Сантыйлана бару** Торган саен ныграк сантыйлану

**Сантыйлана башлау** Аз-азлап сантыйга әйләнү

**Сантыйланып китү** Билгеле бер моменттан соң сантыйлану

**САНТЫЙЛЫК** *и.* Сантый булу; ахмаклык, юләрлек. *Моның сантыйлык икәнен беләм.* М.Кәбиров. *Соңгы вакытта матбугатта, аерым алганда, кайбер шәхесләребез турында язган чакта, «милләтпәрвәр» сүзенең мәгънәсен кечерәйтү, дәрәҗәсен түбәнәйтү күренеше ешайды, бу – сантыйлык чигенә җитү – күңелсез төс ала башлады.* Л.Лерон

**САНЧАК** *и. диал.* Киемгә чәнчеп эләктерелә торган хатын-кыз бизәнү әйбере; брошка. *Алтын санчак*

**САНЧАСТЬ** *и. рус* Санитария бүлеге. *Аны [Әскәрне] санчастька җибәрделәр. Санчастьтан туп-туры өлкәгә – тәҗрибәле күз врачларына озаттылар...* А.Гыйләҗев. *Иртәнгә кадәр ничек кирәк алай түздем дә, алмаш килгәч, санчастька йөгердем.* Ф.Шәфигуллин

**САНЭПИДСТА́НЦИЯ** *и. рус* Санитар күзәтчелек итү һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү учреждениесе. *[Карт:] Анысы безгә мәгълүм түгел! Санэпидстанциядә бер хатын дулаганмы шунда.* А.Гыйләҗев

**САҢАК** *и.* 1) Балык һәм кайбер су хайваннарының суда эрегән кислородны сулау органы. *Мондый очракта артык газ авыз һәм саңаклар аша суга тарала...* Ф.Бәйрәмова. *Мин ике куллап бу шома, әллә ниткән ямьсез балыкны саңак турысыннан эләктердем дә ярга ыргыттым.* Ә.Дусайлы. *Авыз һәм саңак капкачларының хәрәкәте нәтиҗәсендә авызга кергән су саңак куышлыгына куыла һәм, саңак яфраклары аша, саңакларны юып, тышка чыгарыла.* Биология

2) *диал.* Аскы казналык. *Шуңа күрә йөрәк тибеше күкрәгенә генә сыешмыйча, ике як баш миен дә дөпелдәтә башлады, саңаклары тартышыптартышып куйды.* Р.Мәрдәншин

3) *тех.* Балта түтәсенең аскы ягындагы кечкенә чыгынтысы

**САҢГЫРА́У** *с.* **1.** 1) Ишетү тойгысыннан бөтенләй яки өлешчә мәхрүм калган, чукрак. *Син саңгырау колакайга әйтсәң ни дә, әйтмәсәң ни! Туң күчән бит син!* А.Гыйләҗев. *Галимҗан әлеге теге саңгырау карт белән сөйләшеп торганда, бу йортка полковник килеп урнашкан иде инде.* С.Поварисов. *Аңардан соң мал-туар багарга килгән Фатыйма исемле саңгырау бер сазаган кызны Шәмсениса абыстай үзе ярата-сы итмәде.* Г.Ахунов

2) Яңгырап ишетелми торган, басынкы, тонык (авазлар, тавышлар тур.). *Ул, үзенең шаяртуыннан кыенсынып, кинәт тынып калды, куе кашлары җыерылып килде, саңгырау тавыш белән: «Күптән инде кулга мылтык алган юк иде», – дип мыгырданды.* Р.Зәйдулла. *Саңгырау гөрелтеле тавышны Зәки тракторы гына чыгара иде.* Н.Гыйматдинова

3) *лингв.* Тавыш катнашыннан башка әйтелә торган (аваз тур.); *киресе:* **яңгырау**. *Еш кына яңгырау тартыклар урынына саңгырау авазлар да кулланыла: бәпкә – пәпкә, Динә – Тинә.* Ф.Харрасова

4) *күч.* Ачык булмаган, яшерен, чак сизелерлек. *Бала теләү – борынгыдан, күзәнәкләрдә нәселдән-нәселгә геннар күчереп килгән саңгырау бер инстинкт кына икән!* А.Гыйләҗев. *Бу саңгырау хәлсезлек аның бөтен әгъзаларына, ниндидер бер чирнең ашыкмыйча килүе төсле, акрын гына җәелә бара, һәм колаклары эшпошыргыч бер тынлык белән туктаусыз шаулап тора иде.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Басынкы, тонык тавыш белән. *Кыз саңгырау гына көлде.* А.Гыйләҗев. *– Елама, кызым, хәзер әниең янына барып җитәбез, – диде, һәм үз тавышы үзенә баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелде.* Ә.Еники. *Шул чагында теге, кем әйтмешли, Алланың кодрәте белән генә аягүрә басып торган чыршы, саңгырау гына сызгырып, яңадан алан уртасына авып төште.* Ф.Шәфигуллин

**3.** *и. мәгъ.* Колагы ишетмәүче кеше. *Саңгырауның ишетәсе, белмәгәннең беләсе килә...* Р.Гаязетдин. *Мәҗлес мул булды: аракы-шәраб су урынына акты, байлык-җитешлекнең ни икәнен сукыр да күрерлек, саңгырау да ишетерлек итеп тырыштылар!* Р.Мулланурова

◊ **Саңгырау ябалак** Саңгырау кешегә карата кимсетеп, көлеп әйтелә. *[Зәйнәп:] Гарәфи, Гарәфи, Гарәфи, саңгырау ябалак!* Т.Гыйззәт

**САҢГЫРА́У ГӨМБӘ** *и. бот.* Эчендәге йомшагы кипкәч тузанга әйләнә торган, шар формасындагы, халык ышануы буенча, шул тузаны колакка керсә, саңгыраулата торган гөмбә; *русчасы:* **дождевик**

**САҢГЫРАУЛАНУ** *ф.* 1) Саңгырауга әйләнү, ишетми башлау. *Шушы гөмбә череген, кич ятканда, колагыңа өрдер. --- Колагың саңгыраулаөыр.* М.Мәһдиев. *Кара әле, әллә саңгыраулаөган инде бу?* Ф.Дәүләтбаев

2) Саңгырау булып кылану

3) Саңгырауга (*2 мәгъ.*) әйләнү, басынкы, тонык ишетелә башлау (төрле тавышлар тур.). *Баягы тавыш, чаң сугу авазы кебек, еракка китеп, саңгыраулаөып кабатланды.* М.Галиев. *Рәфиснең тавышы саңгыраулаөып, аһ орып чыкты.* А.Вергазов

**Саңгыраулана бару** Торган саен ныграк саңгыраулану. *Җәмгыять аяусызлана һәм саңгыраулана барган саен, кешеләрдә эгоистлык һәм хөсетлек арта төшә...* Н.Хәсәнов. *Шулай итеп, колакларыбыз тавыштан, шаушудан акрынлап саңгыраулана бара.* Мәдәни җомга

**Саңгыраулана башлау** Саңгыраулык билгеләре сизелү. *Колагы саңгыраулана башлаган икән [картның].* Г.Бәширов

**Саңгыраулана төшү** Бераз саңгыраулану; тагын да саңгыраулану. *Бертуктаусыз ничәмә-ничә ел буе микрофоннан акыруларын тыңлый торгач, безнең колаклар да саңгыраулана төшкәндер.* Татарстан яшьләре

**Саңгыраулаөып бетү** Тәмам саңгыраулану. *Режиссёр каян белсен ул тамашачының наушниклар белән болай да саңгыраулаөып беткән колак проблемасы турында?* Х.Ширмән. *Арада ниндиләре генә юк: нечкә тавыш белән исләреңне китәргәннәре дә, калын тавышларын гөлдерәтеп чыгару осталары да, саңгыраулаөып беткән*

*басынкы авазлар чыгарып бакылдауга дучар ителгән картлары да бар.* К.Миңлебаев

**Саңгырауланып калу** *Шушы көннән бәхетсез ана саңгырауланып калды.* Ә.Хәсәнов. *Лейтенант Рәхимов выжт-выжт пулялар очуын да, авыл ягыннан сызгырып килгән снарядларның шартлавын да ишетмәс дәрәҗәдә саңгырауланып калган иде.* Р.Бәшәр

**Саңгырауланып китү** *к.* **саңгырауланып калу**

**Саңгырауланып тору** Сөйләү моментында саңгыраулану. *Бу тавыштан бераз вакыт саңгырауланып торганнан соң, Камил аның Алыплар сөйләшүе икәнен аңлап алды.* Ф.Бәйрәмова

**САҢГЫРАУЛАТУ** *ф. йокл. юн.* 1) Ишетү сәләтен начарайту. *Берсе – үземнән ун метр чамасы арада ярылган снаряд тавышы – бөтенләй тондырды, саңгыраулатты.* Х.Мөҗәй. *Үзебезнекеләр – үз кешеләребез кыйнап саңгыраулатканнар, сул кулының ике бармагын сындырганнар.* Н.Әхмәдиев. *Әче музыка тавышы колакны саңгыраулата иде.* Н.Гыйматдинова

2) Саңгырау итү (авазны). *Хикмәт шунда: безнең якта, [з] авазын саңгыраулатып, «бед бадарга барабыд» дип сөйләшәләр.* М.Маликова

**Саңгыраулата башлау** Саңгыраулатырга тотыну. *– Музыкагыз саңгыраулата башлады, китәм мин, – диде дә чыгып та йөгерде кыз.* Казан утлары

**Саңгыраулатып ташлау** Кинәт саңгыраулату. *Әнвәргә зыяны тимәде, әмма бик каты саңгыраулатып ташлады.* Х.Камалов

**САҢГЫРАУЛАШУ** *ф. лингв.* 1) Тарихи үсеш чорында саңгырауга әйләнү (авазлар тур.). *Кыпчак төркеменә кергән телләрдә сүз башындагы тартыклар саңгыраулаштырылалар.* Ватаным Татарстан

2) Билгеле бер позициядә саңгырау булып әйтелү (авазлар тур.). *Сүз азагында килгән [б] һәм [д] авазлары, татар теленең фонетик законы буенча, саңгыраулаша.* Ш.Рамазанов. *Сүз һәм иҗек ахырында килгәндә, җ хәрефе белдергән яңгырау тартык саңгыраулаша: Минһаҗ, иҗтиһат ---.* Р.Шәмсетдинова

**САҢГЫРАУЛЫК** *и.* 1) Саңгырау (*1 мәгъ.*) булу; чукраклык. *Уйламый уку – аңгыралык, укыганда икенчене уйлау – саңгыраулык.* Мәкаль. *Гариплек, сукырлык, аяксызлык, кулсызлык, саңгыраулык темаларын олыдан куптарырга бер генә татар иҗатчысы да җөрьәт итмәде шикелле.* Р.Батулла

2) Саңгырау (*3 мәгъ.*) булу. *Сүз башындагы [б] авазы саңгыраулык элементы белән әйтелә: пара – бара.* Татар халык сөйләшләре. *Яңгыраулыкта-саңгыраулыкта охшашланган сүзләргә мисал китерү кирәк иде.* Мәгърифәт

3) *күч.* Ишетмәү, ишетмәмешкә салышу, колак салмау, битараф булу хәле. *Хикмәт һич тә саранлыкта гына түгел, ә саңгыраулыкта, сукырлыкта, җайсызлыкта.* Ә.Баян. *Аның еллар буена чигерелеп килүен бюрократиянең таш бәгыре, сәяси саңгыраулыгы белән генә аңлатып буладыр.* Ш.Галиев. *Саңгыраулык, битарафлык чире тагын да хәсрәткә батыра, кыйммәткәрәк төшерә.* Н.Хәсәнов

**САП** *и.* 1) Төрле коралларның кулга тота торган өлеше, тотка, тоткыч. *Каган, тезләнеп, изге кылычның бакыр сабыннан тотты.* Н.Фәттах. *Германрих король хәнҗәр сабын ике кулы белән кысты һәм тынып калды.* М.Хәбибуллин. *Чемодан саплары уч төбенә каразәңгәр эзләр сыза, чемоданнар, кулны гәүдәдән аерып алырга теләгәндәй, аска тарталар.* А.Гыйләҗев

2) Кайбер коралларның эш башкара торган элементын беркетү таягы. *Ук сабы, сөңге сабы ясарга шул яхшы каенлыктан каен кисәргә рөхсәт сорадылар.* Н.Фәттах. *Көнләшеп, төннәр буе каләм сабы кимереп утырып карый, мең бит кәгазь пычрата – шигырь барыбер язылмый.* А.Гыйләҗев

3) *сөйл.* Үсемлек сабагы. *Сары, сары, сап-сары, Сары чәчәк саплары.* Җыр. *Нәзек кенә үлән саплары крояшка таба сузылдылар.* Ф.Әмирхан. *Ишетәм дип, Иркә шунда егеткә таба чәчәк сабы сыман сузылды, кабатлап әйтәм диярәк, Мәсгуть исә кызга авыз сузып якынайды.* Ф.Яхин // Яфрак сабакчасы. *Яфрак сабакта ян урын алып тора, гадәттә, ул яфрак җәймәсеннән һәм яфрак сабыннан тора.* Биология

**САП-** [с] авазына башланган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Каршы тавы, сап-сай инеше дә Түгел дә соң хәйран калырлык.* Ф.Галиева. *Аннан башын түбән игән көе, [Кәрим] әкрен генә кыймылдап, сап-салкын будкага керде.* Л.Шафикова. *Ай сап-сары: алтын күптер анда, Уран күптер таулар-ташларда...* Х.Туфан. *[Карчык – улы турында:] Сап-сау көенчә суга китеп үлде.* М.Гафури. *Кем көтсен хәзер сихәтле, сап-саф кымыз!* Р.Ханнанов

**САПЁР** *и. фр.* Инженер гаскәрендә хезмәт итүче кеше. *Сапёр идем бит мин! Сапёрлар пуля тиеп үлми, күбрәк ертык, тирән яралар алып китә аларны... Акрын үләләр!* А.Гыйләҗев. *...Сапёр көрәкләре белән юеш комны казып, Хисмәтне күмделәр.* М.Мәһдиев. *Ләкин безнең сапёрлар алга китеп кое казыдылар, су таптылар.* Х.Ширмән

**САПИ́НДУС** *и. лат. бот. к.* **сабын агачы**

**САПКАН** *и. тар.* 1) Бау яки каеш очларын тотып, уртадагы киңрәк җиренә таш куеп ата торган борынгы сугыш коралы; зәңгәрт; *русчасы:* **праща**. *Сапкан ату*

2) Ике япьле агач кисәгенә резина беркетеп ясалган, гадәттә таш ата торган ыргыту коралы

◊ **Сапкан ташыдай** Бик тиз, күз ачып йомганчы

**САПКАНЧЫ** *и. тар.* Сапкан белән коралланган сугышчы. *Оста сапканчы*

**САПЛАМ** *и.* Бер тапкыр сапларга җитәрлек җеп. *Көн китә, атна китә, ай китә, ел китә – бер саплам җир китә.* Әкият. *Бер саплам җеп алды да аны хатынының маңгае турысыннан башына урады, аннары колаклары турысыннан җепкә билгеләр ясап, ике өлешкә бүленгән шул җепнең һәр ике яртысын бер-берсе белән үлчәпчагыштырып карады.* М.Галәү. *Җәйге төннең озынлыгы бер саплам җеп кебек кенә икән!* Р.Муллин

**САПЛАМЛА́У** *ф.* Саплам-саплам итеп аеру (җепне)

**САПЛАМЛЫ** *с.* Саплам-саплам итеп куйган (җеп тур.). *Сапламлы җеп*

**САПЛА́У** I *ф.* Сап (*1 мәгъ.*) ясап кую. *Печәнгә төшәр көннәр якынлашып килә: Зартугай халкы, ашыга-ашыга, чалгы саплый, тырма ясый, тәкә симертә.* Г.Ахунов. *Ул [бабай] тирә-күршеләрнең вак-төяк гозерен үти: я көрәк-сәнәк саплый, я чалгыдыр, пычактыр ише әйберләр кайрый.* Н.Гыйматдинова

**Саплап кую** Алдан ук саплау. *Кризис «калдыгы»н күмәргә Саплап куйдым зур көрәк.* Безнең гәҗит

**Саплап тору** Гел, даими саплау яки хәзер саплау процессында булу

**Саплап утыру** Саплау процессында булу. *Иманнан балта саплап утыручы малайларны орыша иде Мирсалих абый.* Г.Гыйльманов

**САПЛА́У** II *ф.* 1) Энә, соса һ.б.ш. нәрсәне җепле итү, аңа җеп кидерү, күзләү. *Әле мин сезнең ничәү икәнегезне күрү түгел, теләсәм, энә саплап җөй тегәм...* М.Галәү. *[Станок] кызу-кызу эшли. Сосаларны да кулга алып тору юк: автоматлар үзләре саплыйлар.* Азат хатын // Җеп кебек нәрсәне энә күзе һ.б.ш. нәрсәгә кертү, кидерү. *Боларны син болай ит, түтиңкә: инәгә беләк буе җеп сапла.* Г.Ахунов. *Хәер, ачык җирләрдә энә сапларлык якты иде әле.* А.Тимергалин. *Аннары ул, изүеннән инәсен алып, яңа җеп саплады да командирга эндәште.* А.Шамов

2) Тоташтыру, ялгау, сабу. *Һәнүзәнең йон оегына баш саплыйм, дидең. Смәтри, кыш җитәр.* Н.Гыйматдинова

**Саплап алу** Тиз арада саплау

**Саплап кую** Алдан ук саплау

**Саплап тору** Саплау белән шөгыльләнү

**САПЛЫ** *с.* Сабы, тоткасы булган; сапланган. *Зарифның баскыч төбенә чыгып, кулындагы озын саплы агач чүмечне әйләндергәләп торуын күрүгә, егетләр бер-берсенә күз кысып, серле генә елмаештылар.* Г.Галиева. *Казанның да төрлесе була ич. Бер төрлесе саплы, учакка асышлы, сылап куела торганы да бар...* А.Тимергалин. *Күзлекле кеше, кесәсеннән саплы зур тарак алып, озын чәчләрен рәтләде.* М.Мәһдиев

**САПЛЫК** *и.* **1.** Нәрсәгә дә булса сап итеп ясарга яраклы яки сап итеп ясар өчен билгеләнгән агач, металл һ.б. төрле материал. *Ул [Нәуширвән карт] рәхәтләнеп көлеп җибәрде, бүкән өстенә куеп юна башлаган себерке саплыгын, янәшәдәге тавыкларны куркытып, йомычка өеменә ыргытты.* Г.Ахунов. *Ихсан кармак саплыкка дип кискән озын таякны такта сарай эченә кертеп куйды, аннары гына йөкне бушатырга кереште.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса сап итеп ясар өчен билгеләнгән, сап ясарга яраклы. *Саплык тал*

**САПОЖКИ** *и. рус* Күннән яки башка материалдан тегелгән озын кунычлы хатын-кыз аяк киеме. *Әле менә бу айда гына, примир, икесенә дә җитмешәр сумлык сапожки юнәттем, пәлтәләрен әйткән дә юк, ике йөз алтмышарга төште...* Ф.Баттал. *Хәзерге кебек колготки, гамаш, сапожки дигәннәрне ишетеп тә белмәдек.* Татарстан яшьләре

**САПРОПЕЛЬ** *и. гр.* 1) Акмый торган төче сулыклар төбендә үсемлекләр һәм тере организмнар черүдән барлыкка килгән ләмле утырма. *Кабан күленең төбендә мең еллар буена җыелган миллион тонна сапропель ята!* Г.Бәширов

2) *тех.* Шул утырмалардан файдаланып җитештерелгән ягулык материал

**САПСАН** *и. зоол.* Лачын кошлар семьялыгыннан оясын кыяларда, агачларда, җирдә кора торган ерткыч кош; чын лачын. *Ясүгәй атына атланып, өйрәтелгән ау кошы – сапсан белән ауга чыккан иде.* Р.Батулла

**САПФИР** *и. һинд.* Зәңгәр якут, сафир. *Патефон аппаратына тавыш буразналардан тимер энә аша түгел, ә сапфир ташы беркетелгән мембрана аша җиткерелгән.* Казан утлары. *Әлбәттә, алтын-көмеш, сапфир ише кыйммәтле ташлар чын түгел, алар хан казнасының муляжы гына.* Шәһри Казан

**САРАЙ** I *и. фар.* 1) Архитектурасы белән гади йортлардан аерылып тора торган зур, иркен заллары булган зиннәтле бина. *Шул кыйшайган мәктәп аңар бик газаматле бер бина, бер сарай, бер мәркәз төсле тоела.* Ш.Камал. *Сарай иде микән, чиркәү микән Менә шушы гөмбәзле бина?* Х.Туфан. *Шулай да баштук алтын сарай вәгъдә итәргә ярамый.* С.Поварисов

2) Патшалар, идарәчеләр, дәүләт башлыклары яши торган зур йорт. *Бәк сараенда йокламыйлар иде. Сарай каршындагы мәйданда учак яна, кызгылт ут шәүләсе тәрәзәләргә төшкән.* Р.Зәйдулла. *Хан сарае тирәсендә еланнар күбәйгән.* Г.Тарханова

3) Җәмәгать оешмалары урнашкан зур бина. *Спорт сарае янынннан тагын трамвай борылды.* А.Гыйләҗев. *Яшь галим Рэй Олдридж Никах сараена барырга әзерләнә иде.* А.Тимергалин

4) *күч.* Монархияле дәүләтләрдә: монархтан һәм аның якыннарыннан торган даирә. *Хәлифә, шагыйрьне ишеткәч, һәр якка эзләүчеләр җибәрде. Җәгъфәрне сарай шагыйре итмәкче булды.* Г.Тукай. *[Таһир:] Күптән түгел сарай киңәш итте... Хөкем итте мине асарга.* Ф.Бурнаш. *Хак булса, Әби патша җәй көннәрендә, бәрәңге чәчкә аткан чорда, үзен уратып алган сарай кызларына чәчләренә бәрәңге чәчәкләре кадап килергә куша торган булган, ди...* А.Хәлим

**САРАЙ** II *и. рус < фар.* 1) Өлешчә яки тулысынча ябык лапас һ.б.ш. хуҗалык каралтысы. *Бу йорт үзе кечкенә булса да, тактадан башы, анбары вә төзек сарайлары иясенең иҗтиһадлытырыш вә хезмәт сөючән адәм идегене күрсәтерләр иде.* М.Акъегет. *Сарай тирәсен дә ныгытасы бар, улак башындагы почмактан су да үтә, түбәне ябарбызмы! Эш күп!* А.Гыйләҗев. *[Нәфисә шүрәле сынын] Я мичкә ягар дип, утын сараена үзем чыгарып куйдым.* Р.Зәйдулла

2) Бурап, күбесенчә идәнләп эшләнгән абзар. *Ике айгырны бер сарайга япмыйлар.* Әйтем. *Тавыклар өчен сарай корырга [булдык].* Ә.Айдар. *Бүлмә дип атарга тел әйләнми хәтта, авылдагы сыер сарае аннан чистарак.* Безнең гәҗит

**САРАН** *с.* **1.** 1) Башкалардан әйберен кызганучан; бернәрсәсен дә кулдан җибәрмәскә тырышучан; карун. *Күрше авылда бик саран, эшлекле, таза тормышлы бер кеше бар иде.* М.Мәһдиев.

*Иң саран кеше дә кешегә киңәшне юмарт бирә.* Ш.Галиев

2) *күч.* Үтә гади, күзгә бәрелеп тормаган, ярлы. *Табигать матурлыкларын кече яшьтән ана сөте белән үк тоеп үскән кешеләр өчен шул саран гына күренешләр дә җитәрлек иде.* Г.Ахунов

3) *күч.* Җитәр-җитмәс булган, бик аз, зәгыйфь. *Кабаклары шешенке күзләре ачылмый гына, Әскәрнең такырлана башлаган киң маңгае өстәл лампасыннан төшкән саран яктылыкта җансыз балавыздай ялтырый, сәмих сагызы төсле куе төкереге ап-ак батист мендәргә тамган.* А.Гыйләҗев. *Шушы саран мәгълүматлар буенча, Икенче планетадагылар, Җирдә шактый алга киткән цивилизация бар, --- дигән нәтиҗәгә килгәннәр.* А.Тимергалин

4) Сирәк, әллә нигә бер генә була торган (күз яшьләре, яңгыр тамчылары тур.). *Тирә-яктагы бу чын җанлылык, ябык, саргайган йөзләрдәге саран куаныч яшьләре, --- эшчән кулларның кайтуы Исхакның арыганлыгын бөтенләй оныттырды ---.* А.Гыйләҗев. *Дәрига башта малае Хәялине танымыйча торган иде, аннары елап та, күзләренең саран ачы яше аша көлеп тә җибәрә иде.* М.Хуҗин

5) *күч.* Юн. килеш. сүздән соң килеп, шунда әйтелгәнне теләр-теләмәс эшләүне яки артык тыйнаклыкны белдерә. *Басынкы, сүзгә саран иреннән шундый сүзләр ишетер көне дә бар икән Нурдиданең!* А.Гыйләҗев. *«Яратам» дигән сүзне борчак урынына сипте Алмабикә. Әмма Галимҗан аңа саран иде.* С.Поварисов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сиздерер-сиздермәс кенә. *– Менә бу чын большевикларча! – дип, саран гына елмаеп куйды Сталин.* С.Поварисов. *Үз кабинетында гына кабул итәргә күнеккән кибар түрә кебек башын кагып куйды, керергә ишарәләп, [Камил] уң кулын саран гына изәде.* Р.Зәйдулла. *Менә юлны урталай кисеп, саран гына саркыган суы белән җирне юешләтеп яткан Тукмак Кулы чишмәсе аша чыккач, юл тауга таба үрли башлады.* А.Хәлим

2) Саранлык белән, кызганып кына; бик аз. *Табигать мондый бүләкләрне бик саран өләшә.* А.Тимергалин. *Безнең ата-бабага да шушы җир ипи ашаткан ашатуын. Тик ул чагында бик назландырып, бик саран ашаткан.* Г.Бәширов

**САРАНА** *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык суганчалы үсемлек, суганлы лалә, бөдрә лалә; *русчасы:* **саранка**. *Сарана төбендә суган ятыр.* Мәкаль. *Кылганнар арасында тамак ялгарлык бернинди үлән әсәре – кымызлык, кузгалак, балтырган, сарана, җиләк сыман нәрсә күзгә чалынмады.* А.Хәлим. *Кыңгырау чәчәкләрен, сарана, дельфиниум, кыргый гладиолус, тубылгы чәчәкләрен күреп сөенәбез.* Шәһри Казан

**САРАНАЮ** *ф. сир. к.* **саранлану**. *[Галим – байларга:] Сез телгә төче, сөйләргә юмарт; кесәгә килгәч, саранаясыз.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**САРАНЛАНУ** *ф.* 1) Саранга (*1 мәгъ.*) әйләнү. *[Кунакка чакырмаган байлардан зарланучы хәзрәт:] Бу елларны алар да саранландылар, чакырмый башладылар.* Ш.Мөхәммәдев. *Аллаһы аларга рәхмәтеннән байлык биргәч, саранландылар, ул байлыкның хакын чыгарудан баш тарттылар.* Безнең гәҗит

2) Саранлык күрсәтү; нәрсәнедер бирергә кызгану. *Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга, Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.* Г.Тукай. *Күршеләргә дә тавыктан өлеш чыгармый булмас, сине, хатыныңны мактап торалар икән, саранланып эш чыкмас.* А.Гыйләҗев. *--- саранлансам юлым уңмас дип, чирәмгә куш учы белән кызыл билле прәннек сибеп җибәрде [Габбас мулла].* Г.Ахунов

3) *күч.* Юн. килеш. сүздән соң килеп, шунда әйтелгәнне теләр-теләмәс эшләүне, тыйнаклык күрсәтүне белдерә. *Ул миңа гел язып тора, мин дә хатка саранланмыйм.* И.Гази. *[Исхак] Элеккегә караганда сүзгә саранланды, кырыслыгы артты.* А.Гыйләҗев. *Аларны илле алты яшьлек чал чәчле шагыйрь абыйсының инде хисләргә саранланган ялкау күңеле, чык бөртекләрен сандугач иртә таңда эчкәндәй, үзенә җыя бара.* Ф.Яхин

**Саранлана бару** Торган саен саранлану. *--- кояш яктысы юан кәүсәле карамаларның калын ябалдашлары каплаган туплауның кара көзгесендә куерып, саранланганнан-саранлана бара.* А.Хәлим

**Саранлана башлау** Саранлык билгеләре сизелү. *Өлкәннәр куркучан, шикләнүчән була, саранлана башлыйлар.* Кәеф ничек?

**Саранланып бетү** Тәмам саранлану

**Саранланып калу** Нindидер бер вакыйгадан соң саранлану. *Нәрсә булды соң әле малайга? Юл маҗараларын рухланып сөйләде дә, кабер турында сүз чыккач, саранланды да калды.* Р.Төхфәтуллин

**Саранланып китү** Кинәт яки соңгы вакытта саранлану. *Шуңа күрә ата-ана өлкән баланың кинәт саранланып китүенең сәбәбен аңламый.* Ватаным Татарстан

**Саранланып тору** Гел, һәрвакыт яки билгеле бер вакытта саранлану. *Куанычым зур булганга, саранланып тормадым – кичер мине, изге анам!* Н.Фәттах. *Укучыларыбыз хатларыннан күренгәнчә, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә губернаторлар, --- вәгъдәләр биргәндә, алай саранланып тормыйлар, ләкин соңыннан барын да җиңел генә оныталар.* Р.Вәлиев

**САРАНЛАШУ** *ф.* Саранлык күрсәтү. *[Нурулла:] Бигрәк тә юмартланып киттең. [Мортаза:] Андый эшкә [эшчене сыйлауга] минем кайчан саранлашканым бар?* Т.Гыйззәт. *Табигать киң басу-яланнар, күркәм кырурманнарны биргән, кешеләре эшсөяр һәм талантлы, ә менә су мәсьәләсендә саранлашкан.* Кызыл таң

**САРАНЛЫК** *и.* Саран (*1 мәгъ.*) булу, каруңлык. *– Нәрсә? – ди кыз. Бу аның гаҗәпләнеп соравы түгел, хуҗаның саранлыгына биһуш калудан әйтелгән сүзе генә иде.* Н.Гыйматдинова. *Кеше бер усаллык белән тулыша, бер шәфкатьлелек белән. Бер саранлык, бер юмартлык белән.* Ш.Галиев

**САРАНЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **саранлашу**. *Ул безнең кайдан килгәнне вә кайларда булганыбызны сораша иде. Без, әлбәттә, саранлык кылмый идек.*

*Башыбыздан үткәннәрне, бер-беребезне бүлеп-бүлеп, өлгерештән сөйли идек.* Ш.Камал

**САРАНЧА** *и.* Турыканатлылар өссемьялыгыннан көтү-көтү булып бер урыннан икенче урынга күчә һәм авыл хуҗалыгы чәчүлекләренә зур зыян китерә торган чикерткәгә охшаш корткыч бөҗәк. *Кайдадыр Себер ягында әсирлектә яткан чехлар баш күтәргән, ак генераллар белән сүз берләштереп, алардан корал алып, саранча явы кебек, Мәскәүгә ашкыналар икән.* Г.Ахунов. *Кап-кара ялтыравык каурый. Кыр тычканы, саранча Ул [кара карга] якынлашкач калмый.* А.Җамалиев. *Авы уңышсыз барганда, [юлбарыс] бака, тычкан, хәтта саранчалар да тота.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр

◊ **Саранча кебек** Тиз арада күбәеп һәм берни белән дә санлашмыйча. *Алар үрчегәннән-үрчи бара, саранча кебек бөтен эстраданы басып ала.* Р.Миңнуллин. – *Юлындагыны саранча кебек юкка чыгарып баручы инвестор бит ул, безне дә шул көн көткәне ике икең дүрт булган кебек гади аңлашыла, – диләр.* Безнең гәҗит

**САРАФАН** *и. фар.* 1) Элекке рус авылларында хатын-кызлар кия торган киң итәкле җиңсез озын күлмәк. *Серафима Ниловна – аз сүзле хатын. --- Өстендә бөрмәләп теккән озын сары сарафан, сүзләре дә бер үк: «Добрый день – до свиданья!»* Г.Ахунов. *Ишегалдына кереп, тарантаслардан төшүгә, безне киң итәкле озын сарафан кигән, тулы гәүдәле, ак чырайлы чибәр генә хозяйка-марҗа ачык йөз белән каршы алды.* Ә.Еники. *Өстенә сарафан кигән Кар кызы кызлар белән бергә урманга барырга әтисеннән рөхсәт сорый.* Ф.Әһлиуллина

2) Җиңсез хатын-кыз күлмәгенең зур изүле, якасыз фасоны. *Коридор башыннан кинәт бакыр төсле шәрә аяклар, шәрә беләкләр килеп чыкты, үтә кыска кызыл сарафан күренде.* Г.Бәширов

**САРАФАНЛЫ** *с.* Сарафан кигән. *Пәнҗәргә җитәргә биш-алты чакрымнар кала, сиртмәле арбага сары бөдрә чәчле, зәңгәр сарафанлы яшь кенә бер хатынны утырттылар.* Г.Ахунов

**САРАФАНЛЫК** *с.* **1.** Сарафан тегү өчен яки шуңа ярарлык, җитәрлек булган. *Сарафанлык ефәк*

**2.** *и. мәгъ.* Сарафан тегәр өчен тукыма. *Сарафанлык алу*

**САРБАЙ** *и. сөйл.* 1) Токымсыз, гадәттә сары, авыл этләренә бирелә торган кушамат. *Бер этебез Акбай, бер этебез Сарбай.* Г.Бәширов. *Сарбай өй нигезенә тәрәлеп ятты.* М.Хуҗин. *Моның исеме – Сарбай, көтүче Камалинең эте.* Ф.Яхин

2) *күч.* Гомумән эт, маэмай. *Үзең сарык булгач, көтүчең сарбай булганга үпкәләмә.* Мәкаль. *Кузгалдык, җәмәгать, без эшлисе эшне озын койрык сарбай килеп эшләмәс.* Г.Ахунов. *Ач этләрне ябып аранга, Кимерелгән сөяк ташладылар: «Сыйланыгыз, – диеп, – сарбайлар!»* Р.Нуруллин

**САРГАЙТУ** *ф.* 1) Сары төскә кертү; сарыга буяу. *Минневәлинең авазы һәм тояк тавышлары бергә бутала, тузан болыты каурый болытларны саргайта.* Р.Бәшәр. *Башта яфрак очларын саргайтты, аннары сабагы да сагыштан зар булган кеше төсле сыгылып төште...* Г.Гыйльманов. *[Хәмидә] алтынга манып саргайткан көмеш тәңкәләр тезеп ясалган калфагын янына алды.* М.Гафури

2) Корыту, сулдыру. – *Чәчәкнең суын алмаштырдыңмы, Сылу? – Файдасы юк, хлорлы су тиз саргайта.* Н.Гыйматдинова

3) Ябыктырып үз табигый төсен алу, төссезләндерү яки саргылт төскә кертү (авыру, кайгы һ.б. тур.). *Чит илләрдә кайгым, сагышларым Саргайттылар күркәм йөземне.* С.Сүнчәләй. *[Бизгәк] һаман килә дә тота, килә дә тота. Яхшы ук мине саргайтты, киптерде дә, ябыктырды да инде.* М.Җәлил. *Җаббар абзый сәкедә авырып ята иде. Сап-сары булып саргайган, күзләре эчкә баткан.* Ә.Фәйзи

4) *күч.* Кайгыга, борчуга салу, тынычлыктан мәхрүм итү. *Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!* Г.Тукай. *«Газзәбануыңны да, Хафизыңны да башка болай саргайтма инде», – дигәннәрен дә Маһирәгә күп ишетергә туры килде ул көнне.* Г.Галиева. *Бер елы, бер көне дә саргайта аның.* Г.Гыйльманов

**Саргайта башлау** Саргайтырга тотыну. *Хәлим ---, күзгә кырау саргайта башлаган беренче чирәмлекне сайлап, атлап килгән уңайга торна баласын читкәрәк куйды да йөзтүбән капланды, аннары, башын күтәреп, аланлыкның аргы башына күз салды.* Г.Гыйльманов

**Саргайта төшү** Тагын да саргайту; бераз саргайту

**Саргайтып бетерү** Тәмам саргайту. *Җылылык торбаларын саргайтып бетерүеңә түздем, ызба уртасына җеп сузып, искеләр элүеңә бер сүз дәшмәдем.* Д.Булатова

**Саргайтып җибәрү** Бераз саргайту

**САРГАН** *и. гр. зоол.* Атлантик океанның Европа ягы ярлары тирәсендә яши торган озын гәүдәле диңгез балыгы

**САРГАЮ** I *ф.* 1) Сарыга әйләнү, сары төс алу. *Әйтәм җирле Гыйззелбәнаттәнең миче бер дә саргаймый, акшарына синке кушадыр, мөгаен...* Г.Галиева. *Күптән түгел котырып бер яңгыр явып үткән иде үтүен, шуннан соң көеп саргайган таулар да яшелләнеп китте, бәрәңгеләр дә көч-хәл алды.* А.Хәлим

2) Ябыгудан төссезләнеп, сары яки саргылт төс куну (тәнгә, кешегә һ.б.га). *Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан ---.* Ш.Камал. *[Эшчеләрнең] берничә ел шунда эшләгәннәренең каннары суырылып, келәт астында үскән зәгыйфь, саргылт үләннәр кебек булып калганнар, йөзләре саргайган, күзләре эчкә батып кергән.* М.Гафури. *Аста Талсылуны югалту хәсрәтеннән саргайган Тал-әнкәне, Курай-малайны үстергән куралы бакчаны, Тәгъзимә әбинең йортын күреп алдылар.* Р.Хафизова

3) *күч.* Бик кайгыру, борчылу, тынычлыкны югалту. *Әнкәй белән сез булмасагыз, әллә кайчан саргаеп үлгән булырыем инде мин.* Г.Галиева. *Аның өчен күпме кыз саргайды бит. Ә ул һаман – Сәлимә дә Сәлимә.* Р.Сәлим. *Ул [бөкре егет] кибә, саргая, җае килгән саен, кызның итәкләрен үбәргә теләп, аның алларына тезләнә.* Ф.Әһлиуллина

**Саргаеп бетү** Тәмам, тулысынча саргаю. *[Китаплар белән кулъязмаларның] Күбесе инде коящта ята-ята саргаеп беткән.* И.Салахов. *[Исмаилнең] кипшегән юка ирен читенә саргаеп беткән юеш тәмәке төпчеге ябышкан иде.* А.Гыйләҗев. *Алты көнне үткәрә алмый саргаеп бетте.* Г.Мөхәммәтшин

**Саргаеп килү** Соңгы вакытта саргаю. *Арышлар саргаеп килә.* К.Тимбикова

**Саргаеп китү** Кинәт саргаю

**Саргаеп чыгу** Тиз арада һәм тулысынча саргаю. *Юкә кайрысы кебек саргаеп чыккан тимер куллары кылыч орышында да, ук бәйгесендә дә үзенә тиңнәрне белми.* В.Имамов

**Саргаеп яту** Бик озак саргаю процессында булу. *Шихуанди сарайларында ун меңләгән, йөз меңләгән яшь кызлар, сөйгән егетләреннән аерылып, кайгыдан-сагыштан саргаеп яталар.* Н.Фәттах

**Саргая бару** Торган саен ныграк саргаю. *Тавык, саргая барып, әтәч артыннан китеп барды.* Р.Сәлим

**Саргая башлау** Саргаерга тотыну. *Колхозның дулкынланып утырган куе, атка атланган кеше керсә дә күренмәслек ашлыгы урынына вак кына, әле баштан ук очлары саргая башлаган башакларын селкетеп, Шакирның ашлыгы утыра иде.* М.Җәлил. *Өй түрендәге миләш ботагында чыпчыклар тирбәнә, читәннәрдә саргая башлаган колмак тәлгәшләре эленеп тора.* Г.Ахунов. --- *үлән ат дугасын күмәрлек булып, котырынып үскән, бүген-иртәгә чалгы тидермәсәң, саргая башлаячак иде.* Н.Гыйматдинова

**Саргая төшү** Тагын да ныграк саргаю; бераз саргаю. *Кыр өсте тагын да саргая төшкән, ул кызуга әлсерәп, мең төрле нечкә авазлар белән чыңлап тора.* Г.Бәширов. *Гали абзыйның ябык һәм авырудан бераз саргая төшкән йөзенә кызыллык йөгерде.* Г.Әпсәләмов

**САРГАЮ** II *и.* Сары төскә керү хәле. *Монысы инде Нурия өчен сүзсез саргаюдан да авыррак иде.* Г.Ахунов. *Йөз саргаюның сәбәбе – кеше организмында (яисә канында) үт суы җыелу.* Татарстан яшьләре

**САРГЫЛТ** *с. ким.* 1) *к.* **сары**. *Сабан басуы дип аталган кырларның күренеше бик гүзәл иде: солы, карабодай вә тары үсеп утырган кырлар күзләргә кызгылт, аксыл, саргылт төсләрдә күренәләр иде.* М.Акъегет. *Өй эче җыештырылган, идән кыргычлап юылган – түшәмгә кадәр саргылт яктылык сирпеп тора.* Р.Зәйдулла

2) Башка бер төскә берникадәр сары төсмер кушылуын белдерә. *Учма ташлаганда, эсседән саргылт зәңгәр төскә кергән күк йөзенә, бик ерак бер читтә хәрәкәтсез асылынып торган ап-ак болыт кисәгенә күз төшереп алалар да: – Һай, шул болытны безнең турыга гына элеп куярга! – диешәләр.* Г.Бәширов. *Еракта, кар диңгезендә, саргылт соры булып утырган ул баганадан сискәнеп, буранда атлар да пошкыралар иде.* М.Мәһдиев

**САРГЫЛТЛАНУ** *ф.* Саргылт төскә керү, саргылт төсмер өстәлү. *Җылы бүлмәдә 2–3 көн торуга су чиста калса, үзагач имин кышлаган дигән сүз, ә инде саргылтланса, башка берәр төскә керсә, агач яшәүгә сәләтсез була.* Бөгелмә авазы

**Саргылтлана башлау** Саргылт төсмер алу

**Саргылтланып китү** Кинәт саргылтлану. *Диңгез төрле төсләргә кереп уйный: әле саргылтланып китә, әле карасу зәңгәр төскә керә.* Казан утлары

**САРГЫЛТСУ** *с. к.* **саргылт**. *[Журналның бу номеры] сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тоник иде.* А.Шамов. *Чишенгәч, бүген ул да, башка кызлар кебек, өстәлендәге көзгесен алып, үзенең йөзен карады: саргылтсу кашлар соргылт күзләрен асларына яшергәннәр, яңаклар заводтагыга караганда суырыла төшкән, яңак сөякләре калкыбрак чыккан.* А.Алиш

**САРГЫЛТЫМ** *с. к.* **саргылт**. *Ул саргылтым көчекне ике кулы белән күкрәгенә кыскан.* Рөс.Вәлиев. *Аларның саргылтым каракучкыл йөзендә ул төснең балкышы күренми дә: кушыла да китә, кушыла да китә...* Идел

**САРДЕ́ЛЬКА** *и. ит.* Кыскарак юан сосиска. *Әмма, шуңа да карамастан, халык барыбер дә составында ите булмаган диярлек, һәртөрле калдыклар, өстәмәләр, тәмләткечләр тутырылган шул казылык, сосиска, сарделька ише продуктларны ала бирә.* Татарстан яшьләре

**САРДИН** *и. лат.* Сельдь семьялыгыннан ашау өчен аулана торган вак диңгез балыгы. *Кәрим аның, күзләрен йома төшеп, тавышсыз гына, сөзеп кенә эчүен азакка чаклы күзәтеп утырды да, Гаптелмәнов, рюмкасын өстәл өстенә куеп, сардинга үрелгәч, стаканын ялт кына эчеп җибәреп, рәхәтләнеп кыяр чәйнәргә кереште.* Г.Ахунов

**САРДО́НИКС** *и. гр. мин.* Төсендә кызыл, ак, көрәнсу һәм көрән буйлар чиратлашкан ярымкыйммәтле таш; ахакның бер төре. *Игезәкләр – юлбарыс күзе, цитрин, сардоникс, барлык чуар һәм буйлы төстәге ташлар.* Ватаным Татарстан

**СА́РЖА** *и. лат.* **1.** Аркау-буй җепләре кыйгач, диагональ юнәлештә үрелеп тукыла һәм гадәттә астар өчен кулланыла торган тукыма. *Кара төстәге саржа дигән тукымадан, эченә мамык кыстырып тегелгән иде ул.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *[Хатын] көрән саржа плащ кигән иде.* Н.Фәттах. *Дәреслекләр тутырган, инде почмаклары ашала башлаган иске сумкасы, үткән ел ук төпләнгән киез итеге, билен чак кына каплаган зәңгәр сырмасы, ак читле көрән шәле, кара саржа күлмәге һәм яшел йоннан бәйләнгән кофтасы.* Ватаным Татарстан

**СА́РИ** *и. һинд* Гәүдәгә берничә тапкыр урала һәм бер очы иңбашына салып куела торган тукыма кисәгеннән гыйбарәт һинд хатын-кызлары киеме. *– Һинд сариена төренгән юк иде, – диде Булавина, халатына тагын да ныграк уралып.* А.Гыйләҗев. *Һиндстан халкы бүген дә – сари, японнар кимоно кия.* Мәдәни җомга

**САРКАЗМ** *и. гр.* Усал, ачы ирония; каһкаһә. *Бу күренешкә каршы ригаясез сатира, үтереп ташларлык сарказм, ачуланган памфлет кирәк иде.* Г.Халит. *Юмористлар табигатьтә еш*

*очрыйлар, сатириклар шактый сирәк, каһкаһәчеләр, ягъни сарказм белән көлүчеләр, бөтенләй юк дәрәҗәсендә кимеде.* Р.Батулла

**САРКА́СТИК** *с. кит.* Ачы ирониялe (сүз, караш һ.б.ш. тур.); каһкаһәле. *Кызга әйтелергә тиешле берсеннән-берсе үткен, берсеннән-берсе саркастик сүзләр килә.* И.Нуруллин

**САРКО́МА** *и. гр. мед.* Тоташтыргыч тукыма элементларыннан барлыкка килә торган яман шеш. *Художник --- саркомадан үлеп китте – бары утыз биш яшендә!* Ә.Еники. *Нәзыйха апаны кырык сигез яшендә саркома дигән чир бу дөньядан алып китте.* Сөембикә

**САРКОФАГ** *и. гр.* 1) Зур таш табут яки табут хезмәтен үтәгән корылма. *Фиргавен саркофагы. Бөек Карлның саркофагы*

2) Чернобыль АЭСның шартлаган энергоблогы өстендә ясалган зур массив саклагыч корылма

**САРКУ** *ф.* 1) Берәр нәрсә аркылы әз генә үтеп чыгу; әз-әзләп кенә агып чыгып тору. *Бүген исә, күңелемдә нидер өзелгәнен --- белеп, туктаусыз сызланып утырганда, теге чактагы яраларымнан һаман кан саркыганда, нигә бу шалтыравык мактау сүзләре?..* А.Гыйләҗев. *Сукыр күзләреннән саркып кына чыккан бер тамчы яшь керфекләренә эленеп калды.* Г.Галиева. *Бер почмакта аунаган өч аяклы нәни казанны алып килдем (ул борынгы илтәбәрнеке иде!) аңа стенадан саркыган суны җыеп салдым.* Р.Зәйдулла. *– Нефть саркымый инде... – диде Таймас.* А.Тимергалин

2) *к.* **сарыгу**. *Сукыр лампага ут кабызып, саркырга куйган чабатамны мич авызыннан барып алдым.* А.Гыйләҗев. *Водокачка янындагы кояшка караган яр башы саркып кибә башлагач та, без шунда кузна уйнарга тотына идек.* Ә.Еники

3) *күч.* Аз гына, сизелер-сизелмәс, беленер-беленмәс булу (аваз, тавыш тур.). *Саркыгандай гына моң кинәт актарыла башлады.* М.Хуҗин. *[Нуриянең] күзләрендә Солтанны кызганудан моң саркып чыккан иде.* Г.Ахунов // Нәрсәдер аркылы бик зәгыйфь кенә үтү (яктылык һ.б.ш. тур.). *Кечкенә такта сараена тәрәзәдән яктылык саркыгач, сукыр лампасының филтәсен баса да тагын яңа эшенә тотына [Талип].* Н.Гыйматдинова. *Яртысы карындык белән капланган бәләкәй тәрәзәдән беленер-беленмәс кенә таң яктысы саркый иде.* Г.Ахунов

**Саркый башлау** Саркырга тотыну. *Аннары ул урыннардан кан саркый башлый иде.* Ватаным Татарстан

**Саркый төшү** Бераз сарку; тагын сарку. *Төнлә су саркый төшәр, иртәгә иртәрәк кыймылдарбыз.* Казан утлары

**Саркып бетү** Саркуыннан тәмам туктау. *Эремчек инде саркып беткәндер, җитмәсә карты да монда утыра, күршеләрнең эте кереп, җәймәгә үрелсә, нихәл итәрсең...* М.Мәһдиев

**Саркып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер сарку. *Сыдырылган, кан саркып торган кулларым белән шул салкын диварга тотынып, капшана-капшана, ишек эзли башладым.* Р.Зәйдулла. *Матрицаның кәрәзләреннән бал түгел, агу саркып тора һәм ул урамдагы такырбашларның кыргый явызлыклары һәм түрдә утыручыларның мәкерле гамәлләре булып бәреп чыга.* Ф.Бәйрәмова

**САРКЫМ** *и.* **1.** Саркып җыелган нәрсә

**2.** *с. мәгъ. махс.* Атмосфера явымтөшемнәре туфракка сеңеп җир астында тупланган (сулар); *русчасы:* **вадозный**

**САРКЫТ** *и. иск.* Хөрмәтле һәм танылган кунаклар табыныннан калган ашамлык яки эчемлек. *Бүлтерек саркытын арыслан җимәк нәчек рәва булыр?* Дастан. *– Хан саркытын эч! – диеп, Идегәйгә биргәндә, Агу салган сараяк Борынына килеп тигәндә, – Ай, борынымны кан кылдың! – дип, Борынын басып, Идегәй Бусагадан атлады.* Дастан

**САРМАТ** *и.* Безнең эрага кадәр VI–IV гасырларда Тубыл белән Дунай елгалары арасындагы территориядә яшәгән күчмә кабиләләр берләшмәсе һәм шуларның бер вәкиле. *Остазы «Галия» мәдрәсәсендә бервакыт төрки-татарлар тамыры булып исәпләнгән скиф, һун, алан, сармат, кыпчак, болгар, хазарлар кебек көчле кавем-кабиләләр турында сөйләгән иде.* С.Поварисов

**САРПИН** *и. иск. к.* **сарпинка**. *– Килегез, килегез, безнең янда йөрегез! – дип кычкырды хуҗамы, приказчикмы, Газизә апаны чакырып. – Үзегезгә сарпин яулыкмы дисез, улыгызга кытат күлмәклекме дисез, рәхим итегез, төреп бирик...* Ә.Фәйзи

**САРПИ́НКА** *и.* **1.** Шакмаклы яки буй-буй юка киҗе тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Сарпинка яулык*

**САРТ** *и. бор. һинд.* Элек-электән Урта Азиядә утрак тормыш алып барган һәм хәзерге үзбәкләр составына кергән халык һәм шуның бер вәкиле. *--- мыексыз җегетләр артындин селәгәйләрен агызып йөргән сартларга ияреп, безнең татарлар хатыннарына бөтен мәхлукат файдаланган якты кояшны күрсәтү хәрам дип тә талаштылар.* Г.Тукай. *Казан ягыныкы без, авылыбыз белән шуннан дисәң дә ярый, бер-ике Бохар сарты бар да, ике-өч төтен себерләр бар, үзебезчә сүләшәбез!* А.Гыйләҗев. *Соңыннан бу дәүләткә кергән төрле төрки кабиләләр – барласлар, карлуклар, сартлар, дөрбәннәр һ.б. – үзбәк дигән исем белән тарих сәхнәсенә менә.* Р.Зәйдулла

**САРУ** I *ф.* 1) Гомумән нәрсәгәдер чорнау, урау (җепне, тасманы һ.б.ш.). *Күкрәгә тәңкәле бишмәт кигән, башына ак урамал сарган киленчәк Айбала егетне елмаеп каршы алды.* Г.Ибраһимов. *Мәрҗани хәзрәтләренең вафатыннан соң, аны кәфенләү, кәфен сару вә күмәргә әзерләү хезмәтләренә катнашты.* Гасырлар авазы

2) Киләп ясау өчен, киләп агачына чорнау, урау (җепне). *Авыз эченнән йомшак кына көйли-көйли, йомгакка уралган җепләрне киләпкә саруын, тулып килгән җеп басмасын үстерүен дәвам иттерде [Сәйдә].* С.Рафиков

3) Пәрәвез җебен таратып беркетү (үрмәкүч тур.). *Юрган астындагы ябык гәүдә аны күрүгә кымшанып куйды, пәрәвезләр сарган сары йөзендә елмаю чалымы сизелде.* Р.Зәйдулла

4) Берәр җиргә җыелып урнашу, туплану (һ.б. тур.). *Күч әкренләп түбәнәя төште. Кая да булса туктап сарырга җыена бу, диде карчык.* Г.Галиев. *Шау чәчәктә утырган юкәләрне меңләгән бал кортлары сарган, алар күңелле генә быздап чәчәк төпләрен тикшерәләр.* А.Гыйләҗев. *Идәндә теткәләнгән линолеум, чебен сарган, мыжлап яталар...* Ш.Галиев

5) Бик күп һәм куе булып тору, еш урнашып һәм бик ишле булып үсү (үсемлек, җимеш, яфрак һ.б.ш. тур.). *Нинди яме булсын алмагачның, Ак чәчәкләр аны сармагач!* М.Җәлил. *Ауган ташлар да бар анда [зиратта]. Язуларын яшел мүк сарган, кырып чистартмыйча аерырлык түгел.* М.Рафиков

6) Урап, чолгап, әйләндереп алу; күп булып җыелу (ишле төркем тур.). *Кешеләр Якупны сарып алдылар һәм төрле сораулар белән күмеп ташладылар.* И.Гази

7) Күп булып куну, ябышу, утыру (тузан, кар, корым кебек нәрсәләр тур.). *Идел буе алмагачларының тамырына, үзәгенә үтә торган, эчке кат тәрәзәләргә тиклем кат-кат зәңгәр сыкы сарган гыйнвар таңы иде.* А.Гыйләҗев. *Карт авыз тирәләрен, сакалмыекларын сарган тир бөрчекләрен кул аркасы белән сөртеп алды.* А.Хәлим. *Юл читендәге бәс сарган куаклар ап-ак учаклардай күккә талпынырга җыена төсле.* Р.Зәйдулла. *Әнинең буркиларына бозланып кар сарган.* М.Кәбиров

8) Томалап-каплап алу (томан, болыт кебек нәрсә тур.). *Зәй буен сарганда күк томан, Хуш исле гөлбакча эчендә Балкый ул [Әлмәт] йолдызлы күк сыман.* Э.Мөэминова. *Болары [очкычлар] машиналардан да күбрәк, кояшны каплап, бөтен күк йөзен сарган, аркылыга-буйга тыз-быз чабыша иде.* Н.Гыйматдинова

9) *күч.* Зур көч белән тәэсир итү, биләп алу (хисләр тур.). *Иң элек почмаклар караңгыланды, Нурулла күкрәгеннән акрын-акрын ташып чыккан хатирәләр өй эчен сарды, стенада аның иләмсез шәүләсен уйнатып, ут чожылдап бөтенләй сүнде.* А.Гыйләҗев. *Сагыш сарды инеш үзәнен.* Д.Йосыпова

**Сарып алу** Тиз арада һәм тулысынча сару. *Җыелганнар, өстәлурындыкларын калдырып, аларны сарып алдылар.* А.Гыйләҗев. *Яр буйларын куе тал, камыш сарып алган, өстен калын боз каплаган Сары суның ике ягында да тигез, ачык далада берничә көн эчендә йөзләгән, меңләгән өйләр калкып чыкты.* Н.Фәттах

**Сарып бетерү** Тәмам бөтен ягын сару. *Бәләкәй, тар юл. Бака үләннәре сарып бетергән үзен.* А.Гыйләҗев

**САРУ** II *и.* 1) Ашказаны суы чыгу сәбәпле, үңәчнең аскы өлешендә барлыкка килә торган әчеттерү тойгысы, үзәк көю. *Кысыла-кысыла, вагончы белән талаша-талаша бардылар, вагоннан чыкканда, икесе дә авызларында әллә нинди күңел болгану, сару кайнау кебек үзгәрешләр сизгәнгә, икесе дә берьюлы лимун берлән чәй эчүне уйладылар.* Г.Исхакый

2) *күч.* Ачуны китерү, эчне пошыру

◊ **Сару кайнату** *к.* **сару кайнау**. *Әмма ләкин алабутаның бары үзеннән генә пешерелгән кап-кара «икмәк» ашар өчен бик әче, бик тәмсез, һәм туклыгы да юк дәрәҗәсендә аз. Өстәвенә үзәкне көйдерә, саруны кайната, эчне дә бозып бетерә.* Ә.Еники. *Башка вакытта Җирәннең тук, тыныч йөзе аның ачуын китерсә, бүген аның кирәгеннән артык шат, ягымлы йөзе саруын кайнатты.* Н.Фәттах. *Теге эт көянтәсен әйтәм... Йөри эч пошырып. Кирә, утыра, тотына сүз боткасы ясап сару кайнатырга!* А.Гыйләҗев. *Тфү, әстәгафирулла диген, авызыңнан җил алсын, иртә баштан әллә ниткән тузга ямаганнарны сөйләп утырасың, саруны кайнатып.* Г.Ахунов. **Сару кайнау** 1) Үңәчтә көйдерү, ачыттыру тою, һәм тамак төбенә әчкелтем су килү. *Иртәдән бирле башы авыртып, саруы кайнап килгән Моратов кызып ук китте.* А.Гыйләҗев. *Үзем бик сызланам, аяклар-куллар сызлый, нык сару кайный, колак ишетми, күзләр начар күрә.* Ф.Бәйрәмова; 2) Ачу килү, ачу кабару, күңел борчылу. *Килгән саен, аягымдагы туфләләрне күреп саруы кайныйдыр мескеннең.* Н.Гыйматдинова. *Шулчак Сабитҗан, хатынының телен тый, дип, Айзаданең иренә җикеренә башлады, ә тегесе саруы кайнап утырган җиреннән кинәт Сабитҗанга ташланып, аны буарга тотынды...* Ч.Айтматов. *Теге иләмсез җыр тынган: Гөләндәмнең колагы тонып, саруы кайнап, студент егетнең җырын туктаткан күрәсең.* Ә.Гаффар

**САРУЛЫ** *с.* Сарылган (киләп җебе тур.), сарып куелган

**САРУТ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан терлек азыгы итеп тә кулланыла торган күпьеллык үсемлек; актамыр, күчтәр. *Ул тигез җирләрдә сарут, ромашкалар белән баллы бабалар да үсә.* А.Гыйләҗев. *Авызына каптан сарут сабакларын өзгәләп һәм үлән суының ачысын тоеп, Атнабай беравык сүзсез ятты.* Г.Ахунов. *Аның янәшәсендә сарут һәм кылган кыякларыннан, үлән төкләреннән талгын искән җилдә аксыл серкәләр оча.* А.Хәлим

**САРУТЛЫ** *с.* 1) Сарут үскән (җир тур.). *Ат кирәк сөрергә, ат кирәк... Җир каты, җирләр тын, сарутлы.* С.Хәким. *Сагындым --- Сарутлы басуныкырымны...* Л.Лерон

2) Сарут катнашкан, араларында сарут та булган (үсемлекләр тур.). *Сарутлы печән*

**САРУТЛЫК** *и.* Сарут күп үскән урын

**САРЫ** *с.* **1.** 1) Лимон, көнбагыш чәчәге, бал төсендәге. *Көзнең сары, моң төсе Йөрәгемә ярамый.* Х.Туфан. *Түбәсе сары ефәк белән капланган ике тәгәрмәчле арбасы янында аның егермеләп атлы-кораллы ире тора иде.* Н.Фәттах. *Аның эчендә кызыл, яшел, сары, тагы да әллә нинди төстәге ваквак чәчәкләкләр бар икән.* С.Поварисов

2) Кызгылт коба, сыек коңгырт, төсе уңган җирән; салам төсендәге (чәч, йон, төкләр тур.). *Озакламый кырыйдагы ишек ачылды, аннан ак алъяпкыч бәйләгән сары чәчле бер кыз күренде.* И.Салахов // Шундый чәчле, шундый йонлы. *Тәрәзә алдына яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, килгәнне каршы ала, киткәнне моңлы күзләре белән озата иде.* Ш.Камал. *– Шушы көннәрдә сары бия колын-*

*ларга тиеш, – диде ир, гаепле тавыш белән.* Р.Зәйдулла. *Диңәләр өстәленә дә сары бөдрә чәчле егет килеп төртелде. Сары егетнең күзләре сыек яшел иде.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Танылган кешеләр тормышындагы имеш-мимешләр, җәнҗаллар, сенсацияләр турында мәгълүмат бирә һәм чагыштырмача арзан бәягә таратыла торган (вакытлы матбугат тур.). *Сары матбугат нәрсә генә язмый?!* Шәһри Казан. *Шунда ук үземнең сары газетада эшләүче гайбәтче икәнемне дә белдем.* Безнең гәҗит

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сары **1.** (*1 мәгъ.*) төс. *Сары матур, сары матур, Сары матур сайласаң. Әллә кайлардан танырмын, Кошлар булып сайрасаң.* Җыр. *Алар җир йөзендәге кызларның берсенә дә охшамаганча матур, барысы да бер төсле аппактан яки бертөсле сарыдан киенгәннәр ---.* Г.Ахунов. *Мена алар сарыга буялган бер капка алдына килеп туктый.* С.Поварисов

2) *мед.* Үт пигментының чамадан артык бүленеп чыгуы сәбәпле, тән һәм лайлалы тышчаларның саргылт төскә керүе белән характерлана торган бавыр авыруы; *русчасы:* **желтуха**. *Сары белән авырып ятканда да, әнисе бу кадәрле үк сөйкемсез түгел иде Ләйләнең.* А.Гыйләҗев. *Имеш, җиз таска карап утырсаң, сары авыруы кача икән.* Р.Хәбибуллина. *Әмма, озак та узмастан, Галимҗан Ибраһимов сары белән авырый башлады.* Р.Батулла

3) *мед.* Күзнең карасына саргылт төс биреп тора торган күз авыруы; глаукома; *русчасы:* **жёлтая вода**. *Озынча күкшел битендә кан әсәре калмаган, күзләренә әллә сары йөгергән шунда, әллә нинди...* Г.Бәширов

4) Йомырка агының уртасындагы сары куе матдә. *Каен суы белән юды башын Әскәр, гөмбә парында утырды, селте ясап карады, чыпчык күкәенең сарысын туглап, шуны башына бәйләде.* А.Гыйләҗев. *– Учак янында утырганда, [Алмышның] аягына утлы күмер чәчрәгән. – Ай-яй... Йомырка сарысы сөртергә кирәк иде.* А.Тимергалин

◊ **Сары авыз** *к.* **сары томшык**. *Әсирлек турында ул сары авызлар нәрсә белә соң, апа?* М.Мәһдиев. **Сары авызлы** Яшь, тәҗрибәсез һәм беркатлы. *Шул Кулеша бит инде сары авызлы учительская егетләренә марксизмның беренче әлифләрен танытты, шул бит инде мәктәптәге татар яшьләрен акны карадан аерырга өйрәтте.* А.Расих. **Сары йорт** *сөйл.* Психикасы какшаган авыруларны дәвалый һәм реабилитацияли торган стационар сәламәтлек саклау учреждениесе; психиатрия хастаханәсе, юләрләр йорты. *Сары йортка барганда юлда эшләнгән бу мәгънәсезлек – алда, тегендә эшләнәчәк мәгънәсезлекләрнең баласы гына булган икән әле...* М.Шаһимәрданов. *Картлар йортында да, «сары йорт»та да үз уңышлары, үз җитешсезлекләре бардыр.* И.Сиражи. **Сары коелу** Тәннең сары төскә керүе турында. *Бавырмы? Минем бавыр туганнан бирле авырта. Өч тапкыр сары коелды.* А.Гыйләҗев. **Сары томшык** Яшь, тәҗрибәсез һәм беркатлы кеше. *Элек, август башларында, Казанга абитуриент кызлар – сары томшыклар килеп тулганда шәп була иде!* А.Гыйләҗев. **Сары төшү** *к.* **сары коелу**. *Ул ябыккан. Шома маңгаена сары төшкән, шашкын күзләре шашкын елтырау белән елтырый.* А.Тимергалин

**САРЫАГАЧ** *и.* Өй җиһазлары ясау, буяу алу һ.б.ш. максатлар белән кулланыла торган кайбер тропик һәм субтропик агач яки куак төрләренең сары төсле үзагачы

**САРЫБАШ** *и. бот.* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле, баллы үлән үсемлек; тиле торма; *русчасы:* **желтушник**

2) Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан сары төсле чәчәкле берьеллык яки күпьеллык үлән үсемлек; какыча, тау уты; *русчасы:* **скерда**

**САРЫ БУЯК** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан кызгылт шәмәхә чәчәкле, озын сабаклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **серпуха**

**САРЫГАН** *и. бот.* Сумахчалар семьялыгыннан саргылт үзагачлы һәм күпереп торган зур-зур себеркәчләргә җыелган вак кына алсу чәчәкле биек куак; *русчасы:* **желтинник**

**САРЫГУ** *ф.* Кибә төшү, кипшерү. *[Яңгырсызлыктан] күлләр дә сарыкты.* С.Хәким

**Сарыга башлау** Бераз сарыгу

**Сарыгып киту** Соңгы арада сарыгу

**САРЫГҮГЕЗ** *и. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан сарык һәм үгезгә хас билгеләре булган куштояклы имезүче хайван; миск үгезе; *русчасы:* **овцебык**

**САРЫЙӨЗГЕЧ** *и. зоол.* Байкал күле һәм шул күл бассейнында яшәгән, нигездә янйөзәрләр белән туклана торган төче су балыгы; *русчасы:* **желтокрылка**

**САРЫК** *и.* 1) Куышмөгезлеләр семьялыгыннан куе йонлы, күшәүче, куштояклы вак йорт хайваны; куй. *Бүре сарык туны кисә дә бүре булыр.* Мәкаль. *Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалгач та шулай була.* С.Поварисов

2) Шул хайванның ите. *Кымыз эчкәннән соң, ак киез уртасындагы тәбәнәк өстәлгә алтын табак белән бер бөтен сарык китереп куйдылар.* Н.Фәттах

3) *күч. гади сөйл. хурл.* Юаш, булдыксыз, надан кеше турында. *Сарык янында батыр, батыр янында сарык.* Мәкаль. *Сарык булсаң, көтүчеләр дә, үзеңнән көлүчеләр дә табыла ул.* Н.Гариф. *--- ә инде чынына килсәк, аңгыра сарык кына түгел, дуңгыз чакларың да бар иде [синең, Сәрвәретдин].* С.Поварисов. *– Әй, мин дә ир башым белән кыз-хатын исемен төрләндереп авыз чайкыйм, тфү, сарык, – диде [егет].* Н.Гыйматдинова

**САРЫКАНАТ** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче су балыгы; *русчасы:* **желтопёр**

**САРЫ КА́РТОЧКА** *и. спорт.* Футбол, гандбол, туплы хоккей, регби кебек командалы спорт төрләрендә уен кагыйдәләрен бозган спортчыга кисәтеп күрсәтелә торган билге. *Чыннан да, бу матч иң күп сары карточка күрсәтелгән финал уены буларак тарихка кереп калды.* Ватаным Татарстан

**САРЫКОЙРЫК** *и. зоол.* Ставридачалар семьялыгыннан җылы суларда яши торган диңгез балыгы; *русчасы:* **желтохвост**

**САРЫКОРСАК** *и. зоол.* Җизбаш кәлтәләр семьялыгыннан аяксыз кәлтә; *русчасы:* **желтопузик**

**САРЫКТАШ** *и.* Валун, зур йомры таш

**САРЫКЧЫЛЫК** *и.* Терлекчелекнең сарык асрау белән шөгыльләнә торган тармагы. *Зинира, Альмира, Роза сарыкчылык фермасында эшлиләр.* Р.Миңнуллин. *Әгәр син сарыкчылык киң җәелгән Кавказ, Урта Азия якларына барып чыксаң, күрерсең: анда көтүченең иң якын ярдәмчесе – эт.* А.Расих. *Авыл хуҗалыгын тотып торган сарыкчылык юкка чыкты.* Ватаным Татарстан

**САРЫЛАНУ** *ф.* Сары төскә керү; саргаю. *Ал йөзеңә әллә нигә бу чакларда Сарыланып ниндидер бер төс чыккан, ди.* Г.Сөнгати. *Яктылык отыры күбәйде: башта алсу төскә керде, аннары җете сарыланды.* Г.Ахунов. *Йолдызлар да артык кайнар яна, ай да сарыланды.* Н.Гыйматдинова

**Сарылана башлау** Сары төс керү

**Сарылана төшү** Бераз сарылану; тагын да ныграк сарылану

**Сарыланып китү** Соңгы арада сарылану. *Беренчедән, чәче кара түгел, коңгырт, хәтта язларын-җәйләрен сарыланып китүчән, шуңа ул ямьсездер, мөгаен, чөнки, аның фикеренчә, чибәр кешеләр кара чәчле булалар.* Ф.Яхин

**Сарыланып тору** Сарыланган хәлдә булу

**САРЫЛА́У** *ф. сөйл.* Сары (I) итү, сары төскә кертү. *Буяуны сарылау*

**САРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сару** I (*1 мәгъ.*). *Ул [шәҗәрә] һәрвакыт карындыкка төрелгән көенчә, берничә кат кәгазьгә сарылып, чүпрәкләр белән бәйләнеп куелган иде.* Г.Исхакый

2) Берәр нәрсәгә чорналу, уралу (үрмәле үсемлек, елан һ.б.ш. тур.). *Аждаһа килеп тә җиткән. Ул агачка сарылу белән Камыр батыр яшеренгән урыныннан чыгып, кылычы белән аның башын өзеп тә төшергән.* Әкият. *Буа буышты Исхак, әмма су күтәрелеп, бәпкә үләннәре сарылган сөзәк ярлар аста калгач, ул моңаеп яр читендә берүзе басып калды: малай йөзә белми иде.* А.Гыйләҗев. *Баш түбәмә былбыл кунган чакта, Елан сарылды гел аягыма...* Зөлфәт

3) Уралып, чорналып иярү, күп булып ябышу (үлән, аның орлыгы һ.б.ш. тур.). *Тигәнәк сарылган койрыгыннан качып котыла алмаган эт сыман, кеше дә гомер буе ябышкан гадәтләрдән аерыла-арына алмый.* Ш.Галиев. *Куе әрәмәләр арасыннан боргаланып узган дымлы тар сукмакта аларның битләренә үрмәкүч пәрәвезе сарылды, яка эчләренә корыган яфрак, чүп-чар, бөҗәкләр кереп тулды.* Г.Бәширов

4) Кочаклау, муенга асылыну һ.б.ш. рәвештә сыену (гадәттә балалар, хатын-кызлар тур.). *Музыкант түзмәс, машинасы-ние белән Рәшитне атып бәрер кебек тоелды да, Динә куркып аның кулларына сарылды.* Н.Гыйматдинова. *Җиде Авыз Мостафа, итәкләренә бала-чагалары сарылган Сәгыйдә, Тәүзихалар, өркегән сарык өере сыман таштүмгәкләр аша ыргып, буза купкан җиргә ябырылдылар.* А.Хәлим

5) Кем яки нәрсә дә булса тирәсенә бик күп булып җыелышу, аны чолгап алу. *Аның [трамвайның] ишекләренә генә түгел, тышкы яктан тәрәзәләренә дә чикләвек кәшәнкәләре кебек ир-ат, яшь-җилкенчәк сарылган иде.* А.Гыйләҗев. *Тора-бара, бу хәлне күреп, аның иптәш кызлары да: – Әнисәгә генә сарылмагыз әле. Биредә менә без дә бар, чиратлашып юарга кирәк, – дип, бер-бер артлы җиңнәрен сызгана башладылар.* М.Шабай

6) Берәр нәрсә янына якын ук килеп елышу (кеше тур.). *Урамның теге ягында яшәүче Гыйльфаннарның капка төбенә ят машина килеп туктагач, Сәламгали түр тәрәзәгә сарылды.* И.Сафин. *Кулларына юеш балчык сарыла, торган саен ул авырая, авырая бара иде.* Ф.Әһлиуллина

7) *күч.* Әрсезләнеп, ирексезләп ияру, яныннан китмәү. *Мин балалар белән бик тиз уртак тел табам, үзләре үк сарылырга торалар.* А.Тимергалин. *Авылда миңа бер кыз «сарылып йөргән» иде, мин яшь әле дип, алмадым.* Т.Гыйззәт

**Сарыла бару** Торган саен күбрәк, ныграк сарылу. *Аның тылсымы сезнең керфекләрегезгә сарыла бара.* Э.Мөбарәкшина

**Сарыла башлау** Сарылырга тотыну. *Шул чак бая гына юл аша бу якка чыгып җиткән аклы-каралы йонлач мәче, бик күптән күрешмәгән дусты кебек, тере бутафориянең янына ук килде дә, ялварулы тавыш белән мияулый-мияулый, аякларына сарыла башлады.* Җ.Юныс

**Сарылып бару** Берсен дә калдырмыйча рәттән сарылу. *Әнә тирә-юньгә күз сал: кызлар егетләрне үзләре кочаклап, муеннарына сарылып бара.* Ватаным Татарстан

**Сарылып бетү** Тәмам сарылу. *Ул аяк-кулларын кура җиләге куакларына сыдырта-сыдырта, тигәнәк чукмарларына сарылып бетеп, атау читеннән әйләнде һәм лапас янына килеп туктады.* Раз. Вәлиев

**Сарылып йөрү** Гел сарылу, сарылу гадәте булу. *– Артыгын бизәнмисең, егетләргә сарылып йөрмисең, – диде Радик.* Ватаным Татарстан

**Сарылып калу** Ниндидер вакыйгадан соң сарылган хәлдә булу. *Килгән саен Фукс бакчасына күтәрелеп караса да, Мирвәли үзенең борчулы күңеленә моңсу хатирә булып сарылып калган очрашуны яңартырга теләми иде.* Г.Гыйльманов

**Сарылып тору** Сарылган хәлдә булу. *Ул [Әскәр] командирга күз алдында томан сарылып торуын, күз чокырларының гына түгел, күз алмаларының да авыртып-авыртып китүен сөйләми булдыра алмады.* А.Гыйләҗев. *Агач күләгәсендә ике шәүлә бер-берсенә сарылып тора иде...* С.Зыялы

**САРЫЛЫ** *с.* 1) Сары төс катнашкан, берәр өлеше яки бизәге сары булган. *Сары сандугач буласың сарылы күлмәгең кигәч.* Г.Тукай. *Зыяның иң элек дикъкатен алган нәрсә – зур мәйданга җыелган халыкның күплеге һәм аның сарылы, аклы вә каралы төстә булып, бертуктаусыз селкенеп, бер яктан бер якка чайкалып һәм авышланып торуы булды.* Г.Ибраһимов. *Алат-болат, Тәңкә югалт, Сарылы янчык, Син кал, бу – чык.* Санамыш

2) Эчендә сарысы булган (йомырка турында – гадәттә, бер сарылымы яки

ике сарылымы, дип сөйләгәндә кулланыла). *Димәк, урыс дигән милләт үзе үк ике сарылы күкәй түгелме соң?* Татарстан яшьләре

3) Катлаулы төсне белдергәндә: сары белән башка нindидер төсләр аралашкан. *Аның очы-кырые күренми торган, иңе-буе кая барып тәрәлгәне сизелми торган өсте кызыллы-каралы, аклы-чуарлы, сарылы-сорылы, аллы-гөлле чәчәкләр берлән чигелгән.* Г.Исхакый. *Монда эреле-ваклы самавырлар, яхшы тимер савыт-сабалар, сарылы-кызыллы юрганнар, паласлар, зурлы-кечкенәле түшәк, ястык, мендәрләр – һәрберсе үз рәте белән буй-буй тезелгәннәр.* Г.Ибраһимов. *Су аларны әкрен генә чайкый, бүрәнәләр өстенә утыртып куйган сарылы-зәңгәрле ике өйне, --- мәтеләр белән бергә, селкетеп тора иде.* Г.Ахунов. *Язиданең өстендә сарылы-яшелле яфраклар сибелгән өр-яңа күлмәк, аягында шуның төсле үк яңа туфли иде.* Г.Бәширов

**САРЫЛЫК** *и.* Сары (**1.**) төс, сары төсмер. *Аның тырнакларында элеккеге сарылыгын югалтып, инде алара башлаган бәбкә тыпырчына.* Р.Вәлиев. *Ул вакытларда көннәре дә озынрак, яфракларның сарылыгы да кояш яктысында нурланып торалар иде.* Ф.Яхин

**САРЫМАЙ** *и.* Эретеп туртасыннан арындырылган сыер мае. *Эт корсагына сарымай килешмәс.* Мәкаль. *Сарымай белән әйбәтләп коймак пешерерсең... сөйләшеп утырырбыз, сорашасы сүзләр дә бар иде.* Ш.Камал. *Әчинә сарымай, сөт өсте, шикәр комы салып, йомырка сытып, сөткә генә басылган камыр, чүпрәсен дә мулрак җибәрсәң, күзгә күренеп кабара башлый.* Г.Галиева

◊ **Сарымай тамызу** Бик аз гына, сүз уңаеннан гына нәрсәнеңдер уңай сыйфатын телгә алу, әйтеп китү. --- *сүз уңаеннан гына әдәбият бакчасына кагылып чыгучы партия-совет әһелләре дә аның исеменә сарымай тамызып үтәләр: кемне дә булса яхшы яктан да телгә алырга кирәк бит!* А.Гыйләҗев

**САРЫ МӘТРҮШКӘ** *и. бот.* Ярабайчалар семьялыгыннан якты урманнарда, аланнарда үсә торган сары чәчәкле үлән яки ярымкуак үсемлек; ярабай. *Аннары [кортка] сары мәтрүшкә, җир җиләге салып, чәй кайнатты.* Т.Нәбиуллин. *Тау битләрендә үскән сары мәтрүшкәне дә, сап-сары гөлбадран чәчәген дә шактый күп җыйдылар алар.* Х.Халиков

**САРЫМСАК** *и.* 1) Амариллисчалар семьялыгыннан гадәттә тәмләткеч буларак кулланыла торган көчле исле, ачы суганчалы үсемлек, бакча культурасы. *Менә шуннан соң үзебезнең якта сарымсак үстереп кәсеп итүчеләр юк микән дигән уй керде.* Саба таңнары

2) Шул үсемлекнең бүлемтекле (тырнаклы) суганчасы. *Безнең рус халкы, әгәр эчәргә уйласа, закускага ачырак нәрсә кабарга ярата: тозлы кыяр, тозлаган балык, суган, сарымсак ише...* Г.Ахунов. *Кирәксенүче табылса, кәбестә, кишер, кукуруз, шалкан, сарымсак һәм суган ишеләрне өйгә үк китереп куялар!..* М.Шаһимәрдәнов

**САРЫМСА́К ГӨМБӘ** *и. бот.* Сарымсак исе һәм тәме килеп торган ашарга яраклы эшләпәле гөмбә; *русчасы:* **чесночный гриб**

**САРЫМСАКЛЫ** *с.* Сарымсак кушылган яки салып әзерләгән (ашамлыклар тур.). *Помидор өстенә икенче коймакны куеп, шул ук эзлеклелектә сарымсаклы майонез ягабыз, помидор тезәбез.* Сөембикә

**САРЫМСА́К ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан ашсу тәмләткече итеп кулланыла торган икееллык үлән үсемлек; *русчасы:* **чесночница**

**САРЫНҖЫ** *и. фар. к.* **сәренҗе**. *Әби әйтә: «Мондый чапанны бохар падишасының угылы гына киядер, – ди. – Сарынҗы», – ди. Ул әле өр-яңы! Өр-яңы! Әби әйтә... сарынҗы искерми, ди.* Г.Исхакый

**САРЫ́-САРЫ** *с.* Нинди дә булса берничә әйбернең барысы да сары төсле булган. *Көрлекләре, тазалыклары белән карарга сокландыргыч чәнечкеле сабакларны сары-сары чәчәкләр сырып алды, чәчәк төпләрендә бодай бөртеге кадәр генә кыярлар күренде.* М.Әмир. *Сары-сары гәрәбә, Тәгәрәсәң тәгәрә. Үпкә түгел, наз гына Булса булыр аз гына*...Н.Арсланов

**САРЫ СУ** *и.* 1) Тәннең авыру урынында җыела торган саргылт сыекча; лимфа. *Җир астында күп эшләп, таш казармаларда тора торгач, аларның [элекке шахта эшчеләренең] тән тамырларындагы кызыл каннары агулы сары суларга әйләнгән.* М.Гафури. *Сары сулы кабырчыклар берәм-берәм ярылдылар, җәрәхәтле тән, җәрәхәтле җан туктаусыз сыкранды.* А.Гыйләҗев

2) Сөт оеганда барлыкка килә торган сыекча; эремчек суы. *Ә менә, әбиләрдән калган гадәт буенча, әчегән сөт яисә катыкның өстенә җыела торган сары су белән юу чәчләргә бөтенләй башкача тәэсир итә.* Ватаным Татарстан

**САРЫ СУ́ АВЫРУЫ** *и.* 1) Организмдагы төрле куышлыкларга яки тукымаларга сары су (*1 мәгъ.*) җыелу белән характерлана торган авыру; *русчасы:* **водянка**. *Аракы белән торган кеше судан үләр (бу дәхи бер мәкальдер), ягъни гомере буена күп аракы эчкән кеше ахырында сары су авыруы зәхмәте белән вафат булыр дигән сүз.* Шәһри Казан

2) *к.* **сары 2.** (*3 мәгъ.*)

**САРЫТАМЫР** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан туры сабаклы, ак яки яшькелт чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **желтокорень**

**САРЫ́ ТУРЫ** *с.* **1.** Гәүдәсе сары **1.** (*2 мәгъ.*), ялы, койрыгы һәм аякларының аскы өлеше кара төсле (ат тур.). *Ул арада басу өстендә күз күреме җирдә кара туры, сары туры, алмачуар, тимер күк атлар, арбалар, чикмәнле, бишмәтле, чабаталы агайлар тагын да күбрәк төште.* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый төстәге ат. *Күршенең сары турысы сабан туенда беренче килде*

**САРЫ́ ТУФРАКЛАР** *и. күпл. махс.* Дымлы субтропикларның яфраклы урманнары астындагы, башлыча балчыксыл ана токымнарда барлыкка килә торган сары төсле туфрак төрләре; *русчасы:* **желтозёмы**

**САРЫ УМЫРЗАЯ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан ачык урыннарда үсә һәм яз башында сап-сары чәчәк ата торган үлән үсемлек; язгы утчәчәк; *русчасы:* **адонис, горицвет весенний**

**САРЫФ** *и. гар. иск. лингв.* Морфология. *Татар сарфы һәм татар нәхүе өстендә юкка гына баш ватмады.* А.Расих

**САРЫ́Ф ИТҮ** *ф.* 1) Чыгымга тоту, файдалану. *Ул халыктан җыйган акчасының байтак өлешен эчүгә сарыф итә иде ---.* М.Мәһдиев. *Бөтен акчамны сарыф итәрмен, әмма сине күзле итәрмен.* Р.Батулла. *Маңгай тире белән тапкан акчаны юкка сарыф итеп кайту булмасмы?* Р.Зәйдулла

2) Бирү, чыгару (көчне, энергияне һ.б.ш.). *Вакытны бушка сарыф итмәк ярамас.* М.Акъегет. *Әллә ул түккән көч, җанын сарыф итеп җырлаган тойгылар мәңгегә тарих диварлары астында күмелеп калырмы?* Г.Ахунов. *Көчне артык күп сарыф итәрлек көндәш түгел иде аңа бу Камилә Хәкимовна.* Ф.Яхин

**САРЫ́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **сарыф итү**. *Сөннәтче бабай, иң авырта торган йиренә суккан кеше кеби, бердән чырайларыны сытты, кашыны чытты. Әллә нәрсәгә бик зур көч сарыф кыла башлады.* Г.Исхакый

**САРЫЧА** *и. зоол.* Карчыга кошлар семьялыгыннан уртача зурлыкта, сузып елаган яки мияулаган кебек тавыш чыгара торган ерткыч кош; елак карчыга

**САРЫЧӘЧӘК** *и.* Халык арасында сап-сары чәчәк ата торган күп кенә үлән үсемлекләрнең гомуми атамасы. *Тар сукмактан барган атның бәкәленә язгы сарычәчәкләр тиеп китә.* А.Расих. *Дымлы тугайда шөлдерле сарычәчәкләр, суга якынрак урыннарда давыл чәчәге, су эчендә – төнбоеклар.* М.Мәһдиев

**САРЫЧЫПЧЫК** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан яшькелт сары төсле, вак кара таплы сайрар кош; *русчасы:* **чиж**

**САРЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **сару**. *Сарышмасын җанга юшкын, дуен, Оешмасын безнең кайнар кан!* Х.Туфан. *Шул табигать музыкасына кушылып, тәрәзә пыяласына сарышып үскән тупылның сары яфраклары талгын гына шыбырдаша.* Ф.Әһлиуллина

**САРЫ ЯКУТ** *и.* Үтә күренмәле көрәнсу сары асылташ; тапас, топаз. *Әгәр дә Альбина үзе алып килмәгән булса, егетнең түшенә дә керәсе түгел сары якут төсле, үтә күренмәле диярлек татлы йөземне өзеп, ханым бармак очларында сак кына Ханбалның иреннәренә якын китерде.* Ф.Яхин

**САРЫЯҢАК** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан саңак капкачлары саргылт төсле елга балыгы; *русчасы:* **желтощёк**

**САСУ** *ф.* 1) Бозылып, сасы ис чыгара башлау. *Кайда, авыл, теге сасыган күлең?* Н.Баян. *Сасыган салат микробларының бу сыйнфый булмаган бәрелешне кыздыра төшүе генә мәгълүм.* Җ.Юныс. *Аморфофаллус исен гадәттә сасыган йомырка, балык яки ит исе белән чагыштыралар.* Ватаным Татарстан

2) Гомумән, бик көчле тәмсез ис чыгару

3) Сасы ис белән тулу (бүлмә, һава һ.б. тур.). *Тик менә яз җиту белән күпер материалларында калган зарарлы ашлама кар суларына кушылып елгага аккан, шуңа күрә һава сасыган.* Татарстан яшьләре

4) Сасы ис иярү, сеңү (берәр нәрсәгә яки кешегә). *Сасыга тимә, сасыма!* Ш.Мөдәррис. *Киемнән дисәң, көздән юып, чистартып салган кием ник бу кадәрле сасырга тиеш соң инде?* Татарстан яшьләре

◊ **Сасып яту** *туп.* Вакытны, гомерне әрәм итеп, буш, кызыксыз яшәү. *Синең кебек тынгысыз егетләргә... ул цехта сасып яту... гарьлек, минемчә.* Ә.Дусайлы

**Сасый башлау** Сасырга тотыну. *Балыклар тиз арада бозылып, сасый башлаганнар.* Татарстан яшьләре

**Сасый төшү** Берникадәр сасу

**Сасып бетү** Тәмам сасу. *Мунчага йөрүен ташлап, үзе дә шул чучкалар кебек сасып бетте бит.* З.Зәйнуллин. *[Закир:] Хәер, Биби әби, минем сүзем бер булыр, кайттым дигәч кайттым, кирәкми, юк, миңа зыяндашлы, янә череп сасып беткән төче зәхмәтле кыз.* Ф.Халиди. *[Үрдәк:] Күлнең тәмам рәте китте, Шакшыланды, сасып бетте...* Г.Шамуков

**Сасып тору** Сасыган булу; сасу процессында булу

**Сасып утыру** *к.* **сасып тору**. *Почмактагы урындыкта керосинка сасып утырса да, бүлмәгә тавык ите исе таралган.* А.Гыйләҗев

**Сасып яту** *сөйл.* Сасу процессында булу. *Бу Сабиров нәстәмне карыйдыр инде – Болак тоташ сасып ята.* З.Зәйнуллин

**САСЫ** *с.* **1.** 1) Бик тәмсез, начар, авыр (ис тур.). *Җитмәсә, кеше тәненнән чыккан әчкелтем-төчкелтем ис белән парашаның сасы исе бергә кушылып, тын алгысыз һава ясый монда.* С.Поварисов. *Иләмән абзыйга булышып йөрүче бер кыю егет базга төште дә, иелеп, як-якка карана башлады, ләкин сасы искә түзмичә кире чыкты.* Т.Нәбиуллин

2) Сасы ис чыгып тора торган; сасыган. *Сезнең авыл буасына сасы су агызганда, балыклар атылды.* Н.Гыйматдинова. *Эшләр харап иде: берәмтекләп чүпләп, симәнгә дип сайлап кына салынган унөч чиләк бәрәңге, череп, сасы тирескә әйләнгән.* Г.Әдһәм

3) Сасы ис сеңгән, сасы ис белән тулган. *Мондый тузанлы, сасы һавалы таш калалар миллион, агуны кайсы таш стеналар арасында суласаң да барыбер түгелмени?* Р.Зәйдулла. *Менә ничә ай ул шушы сасы, пычрак подвалда көн күрә.* Безнең гәҗит

**2.** *и. мәгъ.* Авыр, начар ис. *Килгәнкиткән кешеләр байтак инде Иснәделәр йортның сасысын.* Һ.Такташ. *Фу, фу, бөтен бүлмәне төтен сасысы белән тутырдың. Мине дә, валлаһи, авыруга сабыштырырсың инде.* А.Расих. *Беләләр алар сине, кагылсаң, сасың чыга дип кенә читләтеп узалар.* А.Гыйләҗев

◊ **Сасысы чыгу** Усал кешенең берәр сүзгә яки гамәлгә каршы тискәре реакциясе турында

**САСЫ БАКА** *и. зоол.* Җиңелчә генә сарымсак исе килеп торган койрыксыз җир-су хайваны; җир бакасы, көрәгаяк; *русчасы:* **чесночница**

**САСЫК** *с.* 1) *иск.* Сасы. *Эчтә тулып ятмасын сасык эрен.* М.Акмулла. *Сасык кымыз эчмәгез.* Ш.Мөхәммәдев. *Мин хет ми урынында сасык эрен икәнлеген кычкырып әйтәм, аларның баш эчендә бук тутырылган, сасысы*

*тышка бәреп чыга, син дә ул сасыны тоясың, тоясың – дәшмисең.* Р.Батулла

2) *кимс.* «Булдыксыз, шөкәтсез, юньсез» мәгънәләрендәге кимсетеп хурлау сүзе. *Синең башыңны саклап калыр өчен йөрим, сасык!* Ә.Еники. *Шүрәле башта йөзен чытып маташкан иде дә, өченче чәркәдән соң, гыгы-гыгы килеп, баш бармагын күтәреп маташа, сасык.* Р.Зәйдулла

**САСЫ КӨЗӘН** *и.* 1) *зоол.* Сусарсыманнар семьялыгыннан кыска аяклы, кара көрән төсле кечкенә ерткыч җәнлек. *Сәрби әби калды каушап: «Әй Ходаем! Ни булды икән? Әллә сасы көзән-фәлән керде микән?»* Г.Шамуков. *Аларның келәт астында сасы көзән бар.* М.Мәһдиев

2) *күч. кимс.* Түбән кыланышлы, әшәкелек эшләгән кеше турында. *Әйтегез шул сасы көзәнгә. Тагын да телен тыя алмаса, билләһи дип әйтәм, чебеш урынына муенын борып ыргытам.* Г.Бәширов

**САСЫЛАНУ** *ф. к.* **сасу**

**САСЫЛЫК** *и.* 1) Сасы булу. *Берәр тавыкка шул эләксә, шуның сасылыгына чыдый алмыйча, тавык егылып төшә. Менә шуңа күрә сасы көзән диләр аны.* М.Мәһдиев. *Андагы пычраклык, сасылык.* Безнең гәҗит

2) Сасы ис. *Имченең төкерек һәм әче-төче суларыннан, «Әмерекәнский бәлзәмин» дигән трактор маеннан соң бүлмәдә калдырып киткән сасылыгы, күңелләрне укшытырлык булып, өч көн рәттән торды.* Ф.Яхин. *Әмма хушбуй исен шундук бүлмәгә сеңгән яман сасылык күмеп китте.* М.Кәбиров

**САСЫ СУСАР** *и. зоол.* Сусарсыманнар семьялыгыннан куркыныч килгән вакытта койрык төбендәге бизләреннән сасы исле сыекча сиптерә торган озын каралы-аклы мехлы ерткыч җәнлек; ала көзән. *Америка тайгасында --- кара аю, Канада селәүсене, Америка сусары, сасы сусар кебек ерткыч җәнлекләр; поши, вапити боланы кебек үлән белән тукланучы хайваннар яши.* Материклар һәм океаннар географиясе

**САТА́Й-МАТАЙ** *рәв. сөйл.* Каңгырап, миңгерәүләнеп, аптырап. *Үрдәк – чапан эчендә симергән бай хатыныдыр. Ары да авып, бире дә авып, сатай-матай йөрер.* Г.Тукай. *Аннан соңгы вакыйгалар, сатай-матай күрелгән төш кебек, аны бер эссегә, бер салкынга, әле газапка, әле рәхәткә ыргыттылар.* Г.Бәширов

**САТАШКАН** *с. сөйл.* 1) Акылдан язган, тиле. *Ату... биюче башың белән саташкан картны эзлисең.* Н.Гыйматдинова

2) Уйлап эш итә белми торган, дуамал. *Җиңгәм аңа ачулана: – Я, булыр, саташкан! Баланың күңелен бозып сөйләнәсең шунда... – ди.* Ш.Камал

**САТАШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **саташу**. *Я бу мине алдап саташтыра, яисә үз башымның винтлары бушаган, тигез әйләнми.* Ш.Камал. – *Ничек инде барыбер булсын! – дип кызып китте Идегәй, тегенең саташтырырга теләвен сизенеп.* Ч.Айтматов

2) Ялгыштыру, кемне яки нәрсәне дә булса икенчесе белән бутау. *Егет шундый булырга тиеш: урамнан барасың – каршыңа килгән кыз аягын саташтырып сөртенә.* М.Мәһдиев. --- *әкиятче Шәрифҗан, үз якларын саташтырып, бәләкәйләр ягына килеп кергән икән...* Г.Ахунов

**Саштыра бару** Торган саен күбрәк саташтыру. *Һәр уе Мәсгутьне элеккеләреннән күбрәк саташтыра барды.* Ф.Яхин

**Саташтыра башлау** Саташтырырга тотыну. *Балтач районы полициясенә «гыйшкым» төште, төшләремә кереп саташтыра башладылар.* Безнең гәҗит

**Саташтыра язу** Чак кына саташтырмый калу. *Килен бу сүзләрдән адымнарын саташтыра язып, пар чиләкләренең авырлыгын да тоймыйча атлый.* З.Зәбир

**САТАШУ** I *ф.* 1) Йокы аралаш яки аң югалганда, бәйләнешсез сүзләр сөйләнү. *Төнлә аның йокысы кача, азга гына күзе йомылса – саташа, бакыра, җен суккан адәм сымак кылана.* С.Поварисов. *Габбас мулла юньләрәтле йоклый алмады. Төш күрә дә саташып уяна, төш күрә дә саташып уяна.* Г.Ахунов

2) Ялгышу, буталу (санаганда, сүздә һ.б.ш.да). *Мең кат санап, Мин саташтым: Бер, ике... дүрт – адаштым...* Һ.Такташ. *Китапның хәрефләре әлҗе-мөлҗе килә башлый, юллары саташа, Солтанның башына берни керми.* Г.Ахунов

3) *күч.* Акылдан язу, юләрләнү, диванага әйләнү. *Куркыта мине ул ялгызлык, саташырмын төсле. Китмә!* К.Тимбикова. *Хаҗәт шуннан соң кулын селтәп чыгып киткән, карчык бөтенләй саташкан янәсе.* Р.Зәйдулла

4) *күч.* Кем яки нәрсә белән дә булса артык мавыгу. *Хәзрәткә, абыстайга элгәре шул яше онытылган бабайның «өйләнәм» дип йөрүе көлке кеби тоелса да, Сөннәтче бабайның шул уй берлән саташканыны күреп, каршы килүдә мәгънә юклыгыны сизеп, яткан ягына сыйпарга тотындылар.* Г.Исхакый. *Һаман-һаман Хөсәен белән саташа икән әле бу акылсыз кыз, дип уйлап куйды [Гафур].* А.Расих. *Балачактан бирле очучы булырга хыялланып, зәңгәр киңлекләрне канатлы кош сыман иңләү хыялы белән саташып үскән авыл малае бит ул.* Р.Мөхәммәдиев

**Саташа башлау** Саташырга тотыну. *Аннары каладагы апасына телефоннан шалтыратты: «Әнкәй саташа башлады ахры, кайт», – диеп чакырды.* Д.Йосыпова. *Бала хәлсезлектән йокымсырый да тагын саташа башлый.* Р.Хәбибуллина

**Саташа язу** Чак кына саташмый калу

**Саташып бетү** Тәмам саташу. *Бер генә минутка да күз алдымнан Салих китмәде, бер генә минутка да аның белән иртәгә очрашуым уемнан чыкмады... Саташып бетә яздым.* Ә.Еники. *Ул төнне барыбер рәтләп йоклый алмадым мин. Әллә нинди төшләр күреп, саташып беттем...* Ф.Шәфигуллин

**Саташып җибәрү** *к.* **саташа башлау**. *Бу вакытта казарманың төрле җирләрендә төнге чикерткәләр туктаусыз кычкыралар, --- кичтән арып яткан эшчеләр мышнап йоклыйлар, теге авыру саташып җибәрә...* М.Гафури

**Саташып йөрү** Күптәннән яки гел, һәрвакыт саташу. *Мәхәббәт хакындагы китапларны йотылып укыган, Лермонтов шигырьләре белән саташып*

*йөри торган көннәре иде [Исхакның]...* А.Гыйләҗев

**Саташып китү** *к.* **саташып кую**. *Мохтар көлемсерәп: – Әй, гомердә юкны, әллә ниткән мәгънәсез төшләр белән саташып киткәнмен... – диде.* Ш.Камал. *Мин саташып киттем: андый шәһәр кайда соң әле ул?* М.Мәһдиев

**Саташып кую** Кинәт яки вакыт-вакыт саташу. *Вакыт-вакыт йокы белән аңгырайган акыл саташып куя.* Н.Гыйматдинова

**Саташып чыгу** Ниндидер вакытны саташып уздыру. *[Габбас мулла] Ярты төнгә чаклы шулай саташып чыкты.* Г.Ахунов

**САТАШУ** II *и.* Бик авыр, газаплы төш. *Ләкин бераздан ук аны коточкыч саташулар, куркыныч төшләр изалый башлады.* Г.Бәширов

**САТАШУЛЫ** *с.* 1) Саташу катнаш. *Ярый әле моның ише хәлләр саташулы авыр төш шикелле үтте дә китте.* Ә.Еники. --- *төн урталары узгач кына [Нурия] саташулы авыр йокыга китә.* Г.Ахунов

2) Мәгънәсез, эчтәлексез, буш; ялгыш. *Кичәге очрашу, төптән уйлаганда, очраклы бер эпизод кына ич ул! Кызның, нишләргә белмәгәннән, саташулы буталуы гына!* А.Гыйләҗев. *Саташулы берничә дәрес шулай узды.* М.Мәһдиев

**САТЕЛЛИТ** *и. лат. кит.* 1) Формаль яктан бәйсез, ләкин чынлыкта башка дәүләткә буйсынган ил. *Паулюс армиясе, сателлитлар гаскәрләре белән бергә, бирелмичә, Сталинград камалышында ике фронтка каршы сугыша.* З.Зәйнуллин

2) *астр.* Планета иярчене

3) *тех.* Берникадәр ара белән бер-бер эчле урнашкан тешле тәгәрмәчләрнең берсеннән икенчесенә хәрәкәтне тапшыра торган арадаш йолдызча. *Сателлитлар күчәре. Өч сателлитлы тапшыргыч. Сателлит диаметры*

4) *анат.* Нерв тукымасы структураларына ияргән ярдәмче күзәнәк яки күзәнәкләр структурасы

5) *информ.* Төп сайтның эшен тәэмин итәргә булыша торган ярдәмче сайт

**САТИН** *и. гар.* **1.** Өсте ефәк кебек ялтырап тора торган тыгыз киҗемамык тукыма. *Тәпиеңә дә хәтта ура, Яго, Чолгау итеп ап-ак сатинны ---.* Х.Туфан. *Печән өсте – Габделхәлим кебек кызыл малчыга лафа вакыт. Калайлы сандыкларда шыплап тутырган ситсы, сатин, ефәк.* Г.Ахунов. *Шушы балага бирәр күлмәклек сатин бирер иде ичмасам...* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Хәзер эте-бете, барысы да: «Ситсы күлмәк тә сатин күлмәк, бәз ыштан да фәлән-фәсмәтән!» Бер кисәк акчасы булса, кибеткә йөгерә.* Г.Толымбай. *Гәүдәсенә бик килешле итеп тегелгән бәби итәкле җете ал сатин күлмәген киде.* Г.Галиева

**САТИ́РА** *и. лат. кит.* 1) Усал, ачы көлү; фаш итә торган ирония, һөҗү. *Ул замандагы сатира журналларын карасаң – исең китәр!* Г.Мөхәммәтшин. *Икенче фельетонымда сатирадан бигрәк ирония үзен ачык сиздерә иде.* Ф.Шәфигуллин

2) Чынбарлыкның ниндидер кимчелекләре кискен формада фаш ителә торган әдәби әсәр. *Гейненың сатирасын укыганда, бу шагыйрь колонизаторларны рәхимсез камчылый кебек тоела.* М.Максуд. *Сатирада деформация – фантастик образлар, гипербола, гротеск, алогизм – шулай ук мул кулланыла.* И.Нуруллин

**САТИ́РАЧЫ** *и.* **1.** Сатирик әсәр авторы. *«Идел суы» әсәре Разилнең астарлы киная остасы булуын да, әче сатирачы икәнлеген дә исбатлый.* Р.Батулла. *Ул – заманның алдынгы журналист-публицисты, күренекле юмористы һәм сатирачысы, вакыты өчен яраклы тәнкыйтьче --- һәм яхшы каллиграф.* М.Гали

**2.** *с. мәгъ.* Сатирага оста, сатира яза ала торган. *Г.Камал ул – тумыштан сатирачы әдип.* М.Гали

**САТИ́РИК** I *и. к.* **сатирачы**. *Бөек рус сатиригы Салтыков-Щедрин «Губерна очерклары» исемле әсәрен бастырып чыгаргач, патша хәзрәтләре аны Рязаньга вице-губернатор итеп җибәрә.* А.Гыйләҗев

**САТИ́РИК** II *с.* 1) Сатира белән сугарылган (әсәр, сөйләм һ.б.ш. тур.). *– Уилкины ни өчен утырттылар соң? – Сугыш алласы Марс турындагы сатирик шигырьләре өчен.* А.Тимергалин. *«Уклар» исемендәге сатирик журналны җитәкләүне К. Мотыйгый Тукайның үзенә үк тапшыра.* Р.Рахман

2) Сатираны гәүдәләндерә торган (әдәби образ һ.б.ш. тур.). *Көлке ситуацияләргә, сатирик образларга бай булса да, бу әсәр драма, трагедия түгел.* Р.Батулла. *Аның кулы белән сырланган сатирик рәсемнәр һәм автопортретлар аның сурәтләү осталыгының колачлы булуын тагын бер кат раслый.* Ватаным Татарстан

3) Сатираны яклый, алга сөрә, шуңа хезмәт итә торган. *Верховный Советка сайлау күренеше, җыелышта Сталинның телгә багышланган китабын өйрәнүләр сатирик алымнар белән, вакыты-вакыты белән гротеск дәрәҗәдә язылганнар.* А.Гыйләҗев. *Комедиядә сатирик юнәлеш белән яңаны раслаучы юнәлеш янәшә бара.* А.Әхмәдуллин

**САТЛЫК** *с.* 1) Сатыла торган, сату өчен дип билгеләнгән. *Ачлык өчен сатлык хайван итеп Ерак... вәхшиләргә саттырды...* Г.Сөнгати. *Сатлык мебелебез юк безнең.* Ф.Имамов. *Хөсәен карт --- үзенең сатлык иске скрипка, гитара, мандолиналарын да оныта, табигать туе – язны каршылау вә күзәтү белән мәшгуль буладыр иде.* Г.Гобәйдуллин

2) *күч.* Акча, мал өчен хыянәт эшләргә сәләтле, намуссыз адымга сәләтле. *– Мин синең балчык ояңны туздырачакмын, сатлык Исәнтәй! – дип кычкырды каган, Исәнтәй ягына борылып та карамыйча.* Н.Фәттах. *– Мин сатлык җан түгел. Дусларымны да, каләмдәшләремне дә, халкымны да, ватанымны да беркайчан да сатмаячакмын! – дип кычкырды ул.* С.Поварисов

**САТРАП** *и. фар.* 1) Борынгы Фарсы илендә провинция идарәчесе. *Дәүләтьяров, яңа урында бераз баш-күз алганнан соң, губерна партия комитетына [район җитәкчеләре өстеннән] аллы-артлы берничә хат язды. --- Алар монда, борынгы Персия сатраплары кебек, ни теләсәләр шуны эшләп ятканнар, диде.* И.Гази

2) *күч.* Залим һәм явыз түрә. *Ә патша сатраплары артык котырына.* А.Расих. *Мәчет манарасын кисү күренеше, этисен кулга алулары, Сталин сатрапларының К.Тинчурин, Г.Ибраһимов китапларын яндырулары хәтердә кала торган сүзләр белән ныгытылган.* А.Гыйләҗев

**САТРАПЛЫК** *и.* 1) *тар.* Фарсы илендә: сатрап идарә иткән вилаять, өлкә

2) *күч.* Сатрап (*2 мәгъ.*) булу

**САТУ** I *ф.* 1) Кемгәдер нәрсәне дә булса билгеле бер бәягә бөтенләй бирү. *Аюны үтермәс борын тиресен сатмыйлар.* Мәкаль. *Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп саклап тотар өчен бүләк итәргә тели.* Ә.Еники. *Эчтән сыктаса да, үзен-үзе җиңде: байталын сатарга уйлады [Ахияр].* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Серне чишү, тыелган мәгълүматны тарату, белдерү. *Сер саткан кеше кем булыр дип, [кулга алынган Хәбип] күз алдына Яманташ вакыйгаларын берәм-берәм тезә башлады.* Г.Ибраһимов. *Рудольф Нуриев СССР дәүләте серләрен сата алмый, чөнки ул андый урыннарда эшләмәгән.* Р.Батулла

3) *күч.* Берәүгә карата хыянәт итү. *Ике татар язучысының бер-берсен сатып төрмәгә утыруы кемгә кирәк?* Ф.Бәйрәмова. *«Киб» бөтен эшне харап итте, өстәвенә Вик Дрейны да полициягә сатты.* А.Тимергалин. *Кеше фикере белән куштанланып, сез боерганга ялганлап, бүтәннәрне сатып ирektә яшәгәнче, үз акылыма хыянәт итмичә төрмәдә утыруны мең мәртәбә артык күрәм!* М.Гәрәев

4) *күч.* Исемне, намусны һ.б.ш. сыйфатларны хурлый, кимсетә торган эш эшләү. *Ялгыз калды... Нишләсә дә, Иле исмен сатмады. Тешен кысып, яшен йотып, Йөрәгендә саклады.* Х.Туфан. *Ә хәзер... шушы тиле-тинтәк белән бергә Әскәрнең данын сатып утыргандыр әле...* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Нинди дә булса әхлакый сыйфатка, мәгълүматка һ.б.ш.га ия булгандай кылану, рия белән сөйләү, әйтү һ.б.ш. (гадәттә моңа лаексыз кешеләр тур.). *Менә яхшы мәсләк: куәтле булсын яңа сәүдәгәрләр, театр хәрам ул, нигә кирәк ул – шулай тәкъвалык сатарга кирәк.* Г.Тукай. *Шагыйрьләре дә, мөхәррирләре дә мораль сата.* Г.Рәфикый. *Мондый очракта акыл сатып, төчеләнеп тору кирәкме икән?* А.Гыйләҗев. *Бәлки, алар да беренче очрашканда гыйшык сатканнардыр, алар да, бәлки, бер-берен тизрәк күрер өчен, озын төннәрне сәгатькә карап уздырганнардыр.* Г.Кутуй

6) *күч.* Сөйләү, тарату (гайбәтне, ялганны һ.б.ш.). *Дөресен генә әйтсәк, дускаем, син – Безнең чорның Саламторханы! Ә аның да кайсы диген әле: Фәлсәфәләр сата торганы!* Х.Туфан. *Бабасы шикелле теләсә кайда ләчтит сатып йөрми.* Г.Галиева. *Поэзия дигәндә ул, әлбәттә, хискә бирелеп сафсата сатуны түгел, ә шигъриятнең бөтен бер арсеналыннан файдалануны күздә тота.* Р.Зәйдулла. *Алар, ирлехатынлы, кашык-мендәр бүлә-бүлә аерылыштылар, бер-берсенең яманатын сата-сата гайбәт чәчтеләр.* Н.Гыйматдинова // Оештыру, ясау, алып бару (әңгәмәне һ.б.ш.). *Болар югары уку йортларына керәчәк, комсомол лидерлары булачак, кеше бәхете турында гәп сатачак.* Р.Зәйдулла

7) *күч.* Уйлап бетерелмәгән берәр гамәл кылу яки дуамаллык эшләү. *[Исерек хәлдә] йорт алдына чыгып, Гыйлаҗиның анасын тотканмын да, миңа кызың Гайнияне бир, мин аңа гашыйк булдым, ул – тирә-якта бер кыз, дип ахмаклык сатып беткәнмен.* Г.Ибраһимов. *[Әхмәт – бюрократ хезмәткәргә:] Юләрлек сатмагыз, зинһар өчен.* Ш.Камал

◊ **Сатып бирү** *к.* **сатып җибәрү**. *[Искәндәр – булдыксыз егет турында:] Ишәк! Шәрәф бит моны сатып бирер!* М.Фәйзи. **Сатып җибәрү** Кешеләр белән мөгамәлә итүдә, хәйләдә-үткенлектә бик оста булу турында. *Гыйлемгә оста алар, сине-мине сатып җибәрәләр.* Г.Мөхәммәтшин

**Сата башлау** Сатарга тотыну. *– Тагын акыл сата башлаячак бит инде. Фаталист! – диде ризасызланып Галия.* Р.Гаязетдин. *Кая барып кагылма, шунда акыл сата башлыйлар.* Раз.Вәлиев. *Кибетләрдә шикәр комын 800–900 граммлы пакетларга салып сата башладылар хәзер.* Татарстан яшьләре

**Сатып алу** Тиз арада сату. *Ул сүз уңаеннан Габдулла Кариевның гайбәтен сатып алды.* А.Расих

**Сатып бару** Берсен дә калдырмыйча һәрберсен рәттән сату. *– Көннекен көнендә сатып барабыз, – диләр кибетчеләр.* Ватаным Татарстан

**Сатып бетерү** Берсен дә калдырмыйча сату; сату эшен тәмамлау. *Фатирында бар кыйммәтле әйберләрне сатып бетерде.* Р.Ахунова. *Хәзерге вакытта складларны да сүтеп сатып бетерделәр.* Безнең гәҗит

**Сатып йөрү** Һәр җирдә, гел сату. *Ят җиргә басуга сәгать сатып йөрү туган ил төсен сатып йөрү кебек лаексыз шөгыль булып тоелды.* З.Мәхмүди. *Шулай да: «Үзе соң, үзе, ирен үтереп, кабергә илтеп тыкты, какча сөяккә калдырып, ашарына да пешермичә, авыл буйлап гайбәт сатып йөреп...» – дигән сүзләрнең чыганагы булды.* Ф.Яхин

**Сатып карау** Сатып булу-булмавын сынау, сатып җибәрергә тырышу. *Карт сыерны узган җәйдә үк сатып караган булган.* Р.Гаязетдин. *Юлчыларның ашыйсы килә торгандыр дип, бәрәңге пешердем дә янына тозлы кыяр куеп сатып карадым.* Ватаным Татарстан

**Сатып килү** Күптәннән бирле сату. *Спайсларны да бит, наркотик матдә булуын исбатлаганчыга кадәр, законлы рәвештә сатып килделәр.* Ватаным Татарстан

**Сатып кую** Тиз арада яки алдан ук сату. *Мөгаен, иптәшләре киңәш иткәндер: әгәр журналда бүлгәләп чыгарсаң, янәсе, кызыклы әсәрнең тәме китәчәк, һәм шагыйрь аны, китап итеп бастырыр өчен, үзе дә сизмәстән, Гыйльметдин Шәрәфкә сатып куя.* М.Зиннур

**Сатып ташлау** Уйламыйчарак, ашыгыбрак сату. *– Күрәсеңме, ул нинди башлы, син аңламаганнарны да җиңел генә төшенә! – дип, көтмәгәндә егете белән мактанып, очсызлы сафсата сатып ташлады.* Ф.Яхин. *Өйне очсызрак сатып ташлау*

**Сатып тору** Әледән-әле яки хәзер, әле сату. *Ул ерагайганчы, Туңгак алып ирләр белән беравык гәп сатып торды.*

Н.Фәттах. *Шуның капка төбендә генә гел пиво сатып торалар.* Г.Мөхәммәтшин

**Сатып яту** *сөйл.* Сату процессында, саткан хәлдә булу. *Тыныбыз куырылып йөгереп барсак, чынлап та [кибеттә бүрекләр] сатып яталар.* Х.Сарьян

**САТУ** II *и. сөйл.* Сату (I) эше, сәүдә. *Гомумән, Татарстанда балык үрчетү, балык тоту, саклау һәм сату мәсьәләләре ничек куелган?* А.Гыйләҗев. *Урам ягы гел пыяладан гына корылган зур магазинда сату эшләренең кайнап торган чагы иде.* Г.Галиев. *Гәрчә балалар сатуның корал белән сәүдә итү, наркобизнес кебек төшемле гамәлләр рәтендә булуы ачык...* Р.Зәйдулла

**САТУ-АЛУ** *и.* 1) Сату һәм алу гамәлләре, шундый эшләр. *Касыйм татарлары, Сергач мишәрләре, нижгарлар Россиянең төрле калаларында, шул исәптән Мәскәүдә дә, Петербургта да сату-алу итәләр.* Г.Ахунов. *Мәскәү тирәсендәге торфлы, уңдырышсыз җирләр генә ярлы дворяннарны канәгатьләндерми башлый, ә сәүдәгәрләргә исә, Шәрык илләре белән сату-алу итәр өчен, Идел буен тулысынча үз кулларына төшерү ихтыяҗы туа.* Р.Зәйдулла

2) Сәүдә эше. *Тук халыкны, сату-алу белән кайнашкан нэпманны совет бик каты китереп кысты, шатырдатып налог сала башлады.* Г.Ахунов. *Ә Уй елгасы артында Меновой двор, казак, татар аны «Минауный» дип атый. Ул – сату-алу урыны, малга товар алыштыру, алдану һәм алдашу эшләре шунда башкарыла.* А.Расих

**СА́ТУ ИТҮ** *ф.* Сәүдә эше белән шөгыльләнү. *Роддомда иң кыен хәлләрдә әллә кем хатыннары белән яттык, дип сөйләде үзе, завод директоры хатыны яткан, профессор хатыннары, үзе шунда азык-төлек ларёгында сату итүче Хания апа белән генә дуслашып чыккан.* А.Гыйләҗев. *Кыска гына гомерле нэп вакытында Гали абзый Дәүләкән базарында әүвәлгечә ит белән сату итте.* Ә.Еники

**САТУЛА́У** *ф.* Товарның бәясен сорап, белешеп карау, бәяне төшерергә тырышу. *Ачы сүзле сәүдәгәрләр ат сатулый.* З.Бәшири

**Сатулап карау** Сатуларга тырышу

**Сатулап тору** Сатулау процессында булу

**САТУЛАШУ** I *ф.* 1) Сатучы һәм алучы арасында, эш килешкәндә һ.б.ш. очракта бәяне үзгәртү турында сүз алып бару. *Кәҗәгә акчасы җитми, сыер сатулаша.* Мәкаль. *Ул елны Чепья базары, анда сатулашып алган ярты пот арыш оны, ике чиләк вак утырту бәрәңгеләре онытылды.* М.Мәһдиев. *Төрек ул сатулашырга ярата.* Р.Зәйдулла

2) Нәрсәгә дә булса ирешергә, файда итәргә теләп бәхәсләшү яки даулашу. *[Эшчеләрнең] берәм-сәрәмнәре промыслодан промыслога барып хезмәт хакы турында сатулаша, урын сайлаштыргалап йөриләр.* Ш.Камал. *Ә Мифтах карт, бирнәсез кызны шушы Иске Кәшер «урыс»ыннан башка сораучы булмас, дип уйлады ахры, артык сатулашмады.* Л.Шафикова

**Сатулаша башлау** Сатулашырга тотыну. *Китәләр болар базарга, Сәйдәш сөт сатучы татар хатыннары янына килеп сатулаша башлый.* Р.Батулла. *40 фунттан сатулаша башлаган бер ручканы 10 фунтка сатып алдык.* Безнең гәҗит

**Сатулаша тору** Бер эш барышында сатулашу. *Ә мин аңардан балык сатулаша торыйм.* Г.Ахунов

**Сатулашып алу** Аз гына сатулашу. *Базарда сату-алу вакытында күнегелгәнчә, бераз сатулашып алырга ниятләгән идем.* Безнең гәҗит

**Сатулашып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзерге вакытта сатулашу. *Бу сатулашып тормый, бер сум түли дә кызыл әтәчне тотып алып китә.* Әкият. *Үз хәлен үзе белгәнгә, Өлфәт сатулашып тормады.* А.Тимергалин

**САТУЛАШУ** II *и.* Сатулашу (I) процессы. *Габбас мулла, сатулашуның соңгы ноктага килеп җиткәнен аңлап, ялварулы тавыш белән әйтте: – Габделхәлим абзый, мин сине мал-мөлкәтле кеше дип түгел, кайнагай дип килдем.* Г.Ахунов

**САТУРА́ТОР** *и. лат. тех.* Сыеклыкны газ белән туендыра торган аппарат

**САТУРА́ЦИЯ** *и. лат. тех.* Сыеклыкны газ белән туендыру

**САТУРНИЗМ** *и. лат. мед.* Кургаш белән хроник агулану

**САТУ́ САТУ** *ф. к.* **сату итү**

**САТУЧЫ** *и.* 1) Сатып алучыларга товар биреп, исәп-хисап эшләрен башкаручы кибет хезмәткәре. *Үзәк универмагта сатучы булып эшли, дигән иде аны Гайфи.* А.Гыйләҗев. *Мин эшләгән кибеттә сатучы үзбәкләр, нишләптер, мине бик якын иттеләр.* Г.Галиева. *Сатучы хатын бик тере булып чыкты, мул түше белән күземә керә язып: – Бездә бөтен нәрсә бар, – диде.* Р.Зәйдулла

2) Вак сәүдәгәр. *Ул, авылның сатучысы Әхмәдинең кызылга буяган өенә охшамаган кеби, авылның иң фәкыйрьләреннән хисаплана торган капка каравылчысы Садриныкына да охшамаган иде.* Г.Исхакый. *Кыз исә аны моннан бер ел элек чит ил сатучыларыннан алып калган һәм бары шушы көн өчен генә сакланып тотылган ят җимешләр белән, ит, кымыз, каймак белән сыйлады.* Н.Фәттах. *Мондагы эре сәүдәгәрләр генә түгел, вак сатучылар да – йортлы-җирле кешеләр.* Ә.Еники

**САТУЧЫЛЫК** *и.* 1) Сатучы һөнәре һәм эше. *Ләкин бер атнадан ук, белүе эшкә ярамаганга, сатучылыкка күчте.* Г.Исхакый. *Алия, сатучылыкка укып чыгып, менә унбиш ел инде, Уфадагы махсус кибеттә совхоз продукциясен сата иде.* Д.Булатова

2) Сату эше, вак сәүдә. *Сатучылык итә бездә мөхәррир, Әдип исме аңар таглыр-тагылмас.* Г.Тукай. *Яшь вакытында ул 25 ел гомерен «Росторгодежда» базасында экспедитор, 15 елын сатучылыкта эшләп үткәргән.* Өмет

**САТЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сату** I (*1, 2, 4–7 мәгъ.*) *Беркайда бернәрсә сатылмый: кибетләр күптән ябылып бетте.* Ә.Еники

2) Сатылмыйча тормау, ятмау; үтү (товар тур.). *[Хакның] яртысын акчалата биргәч, [сәүдәгәрләр], әлбәттә, үзләренә кул булмаган, үтмәс товарны алмыйлар. Яхшы карап, хакын сәүдәләшеп, үзләренә кирәкле һәм сатыла торган маллардан алалар.* Ш.Мөхәммәдев

3) *күч.* Берәр нәрсә хакына даирәңнән, карашларыңнан ваз кичү; хыянәт итү. *[Баязит Гарифуллин] Эштән туймады, дөньяның арзанлы кызыкларына алданмады, сатылмады, сатмады, гадел яшәде.* А.Гыйләҗев. *«Алмабикә» сүзен ишеткәч, аның шул карт «алаша»га сатылганын белгәч, Галимҗанның аркасыннан бер көтү кырмыскалар йөгереп үткәндәй булды.* С.Поварисов

**Сатыла бару** Булган берсе рәттән сатылу. *Симертелгән чучкалар мул акчага сатыла барды.* Н.Гыйматдинова

**Сатыла башлау** Сатылырга тотыну. *Хәзер менә шуңа охшаш порошоклар интернет челтәрендә сатыла башлады.* Ватаным Татарстан

**Сатылып бару** *к.* **сатылып тору**. *Проект, берсүзсез, уңышлы, чөнки билетлар инде август аена сатылып бара.* Безнең гәҗит

**Сатылып бетү** Бөтенесе дә сатылу яки сатылу эше тәмам булу. *Билетлар алдан ук сатылып беткән.* Р.Төхфәтуллин

**Сатылып йөрү** Озак вакыт, күптән яки һәрвакыт сатылу. *Кайда бай күрсә, шуңа сатылып йөри.* В.Юныс. *Эрелеваклы бүләкләргә сатылып йөрсәм, мин Туфан Миңнуллин була алмаган булыр идем.* Т.Миңнуллин

**Сатылып тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле сатылу. *Халык аның «Приора»сын да, «Самара»сын да ала, шулай ук «бишле» һәм «җиделе»ләр дә сатылып тора.* Татарстан яшьләре

**Сатылып яту** *сөйл. к.* **сатылып тору**. *Әмма шул ук вакытта базаркибетләрдә Русиянең үзеннән – Япония белән чиктәш Приморьеда тотылган балыклар сатылып ята.* Татарстан яшьләре

**САТЫ́П АЛУ** *ф.* 1) Билгеле бер бәя түләп, үз милкеңә әйләндерү. *Бозавын сатып алганда, сыеры турында сораш.* Мәкаль. *Акчаңызны юкка-барга сарыф итмәңез, вәләкин үз дәрәҗәңезгә муафикъ нәрсәләр булганда, кысып та тотмаңыз – һәммәсен сатып алыңыз.* М.Галәү. *Әйләнеп кайтса, байталны кире үзенә сатып алыр иде.* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Акча, бүләк кебек нәрсәләр биреп, берәүне үз ягыңа аудару. *[Аклар офицеры] бу төчеләнүләре белән мине сатып алмакчы булган икән.* Г.Гобәй

**САТЫ́П АЛУЧЫ** *и.* Сәүдә хезмәтеннән файдаланучы, мөштәри. *Аннары сатып алучылар аны, кирәкмә-түгелме, бүләк-мазар итеп шунда эшләүчеләргә, килгән кунакларга тарата, мөгаен.* Р.Зәйдулла. *Икенче көнне ат абзары янына таныш булмаган кешеләр киләләр. Болар – сатып алучылар.* Н.Гыйматдинова

**САТЫШ** *и.* 1) Сату гамәле. *Сыктау-сыкраулар белән чүпрәк сатыш, алыш-биреш башлана, күрше-күлән безнең өйгә җыела.* Н.Гыйматдинова

2) Сату рәвеше. *Сатыш алдаусыз булсын!*

3) Сатылган товарның гомуми күләме, дәрәҗәсе. *Нефть сатышы ике миллион баррельгә җитте*

**СА́У** *с.* **1.** 1) Саулыгы, сәламәтлеге булган; авыру түгел. *Шәһәрдә һава җитеп бетми, үпкәләрем бик үк сау түгел, таш өйдә бөркү, тын алуы читен.* А.Гыйләҗев. *Соң, мин әйтәм, киленкәем, сау кеше моны сөенә-сөенә эшли бит, диюем.* Р.Сәлим

2) Исән, тере. *Киләчәккә – алга түгел, Артка китү генә бу. Формализм сау икәнне Исбат итү генә бу.* Х.Туфан. *Болай дип уйлыйм мин: була, шундый хәлләр дә бик була, сау чагында тегеләр яки бу кеше белән әйбәт кенә исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашып йөргән буласың, ул кеше җир куенына мәңгелеккә иңгәч, --- җан тамырлары битараф кала.* А.Гыйләҗев

3) Бозылмаган, ватылмаган, бөтен (әйбер тур.). *[Зонтның] сабы ничектер бераз кәкрәеп киткән, әмма башка җирендә бернәрсә юк, болай сау, таза үзе.* Ш.Камал

**2. саумы** *ы. мәгъ.* Очрашканда сәламләшү сүзе. *– Саумы, килен! – диде һәм килене кулыннан баланы алды да, икенче кулы белән киленнең иңеннән кочты. – Төкле аягың белән, балакай.* М.Хәбибуллин. *«Саумысыз, абзыкайлар», – дип, безнең белән исәнләшә [Шүрәле]!* Р.Зәйдулла

**3.** *рәв. мәгъ.* Хәвеф-хәтәрсез, тыныч кына, исән-имин килеш. *Нәфисә, аңа кулын сузып: – Шулай да иң элек исәнләшик әле, Гөлсем, сау гына килеп җиттеңме? – диде.* Г.Бәширов

◊ **Сау бул** 1) Саубуллашканда әйтелә торган сүз. *Сау бул, түземсезләнеп хатыңны көтәм.* Г.Галиева. *Без тамбурга сикереп мендек. – Сау бул, әтием! – дип кычкырдым мин.* Р.Зәйдулла. *– Юк, ашыгам, сау булыгыз! – диде Фәйрүзә капыл гына.* Н.Гыйматдинова; 2) «Рәхмәт» сүзенә кайтарып әйтелә торган сүз

**САУ-АМАН** *с. к.* **сау-имин**. *Исән калып, сау-аман илгә кайтуның куанычын мең үлемгә шаһит солдат кына белсә беләдер, улым.* А.Гыйләҗев

**САУБУЛЛАШУ** I *ф.* 1) Аерылышкан вакытта бер-береңә исәнлек-саулык теләү. *Саубуллашырбыз күпердә, Безне күрмәс беркем дә.* Х.Туфан. *Ә хәзер табынга утырып капкалап алыгыз да саубуллашырбыз, соң инде.* М.Хәбибуллин. *Нургали бераз тынычлангандай булып, саубуллашып чыгып китсә дә, үзен борчыган шикле уйларыннан өенә кайтып җиткәнче арына алмады.* Г.Галиева

2) Нинди дә булса җир, урыннан китү, шуның белән аерылышу. *Менә шагыйрь, пар атка утырып, «гомер иткән» шәһәре белән саубуллаша да Казанга юл тота.* И.Нуруллин. *Акча мәсьәләсе канәгатьләндермәгән баскетболчыларга исә Казан белән саубуллашырга туры килгән.* Татарстан яшьләре

3) *күч. гадәттә ирон.* Кемне яки нәрсәне дә булса югалтырга мәҗбүр булу, аны кулдан ычкындыру, аннан мәхрүм ителү. *Ул саулыгы белән саубуллашты.* Ә.Фәйзи. *Болай булгач, Нурия яшьлеге белән көзен саубуллаша.* Г.Ахунов. *Аннары машина белән саубуллаштык.* А.Тимергалин. *Ара башладымы, киек тормыш белән саубуллашсын инде...* Т.Нәбиуллин

**Саубуллаша башлау** Саубуллашырга тотыну. *– Китсәгез, инде хуш иттек... – дип, мулла белән саубуллаша башладылар.* Ш.Камал. *Шәмгунның сөйләгәнен башка бер генә минут та тыңлый алмас дәрәҗәгә җиттем һәм тиз-тиз саубуллаша башладым.* Ф.Шәфигуллин

**Саубуллаша тору** Кемнәрдер житешкәнче, алардан алдарак саубуллашу

**Саубуллаша язу** Чак саубуллашмый калу. *Батыршаны куркытып сорау алган вакытта, аның файдасыз җавапларына нервысы кузгалып, губернатор Иван Неплюев, авызыннан күбекләр чәчеп, утырган җиреннән идәнгә ава, бу икенче чираттагы инсульт булып, ул дөнья белән саубуллаша язып, озакка урын өстенә ята.* Бөгелмә авазлары

**Саубуллашып бару** Бөтенләй саубуллашу чигенә якынлашу. *Татарстан җиңел нефть чоры белән саубуллашып бара дияргә була.* Әлмәт таңнары

**Саубуллашып калу** Саубуллашырга өлгерү. *Әйтерсең әле генә су дөньясыннан җир дөньясына күчкән сабый баланы күреп, аның белән саубуллашып калырга тели ул...* Г.Гыйльманов

**Саубуллашып тору** Берникадәр вакыт яки хәзер, әле саубуллашу. *Шуңа күрә озаклап саубуллашып тору катгый тыела.* Ватаным Татарстан

**Саубуллашып чыгу** Берсен дә калдырмыйча һәрберсе белән саубуллашу. *Китәсе көнне иртүк Валия, өйдән-өйгә кереп, һәр кеше белән аерым-аерым саубуллашып чыкты.* Р.Батулла

**САУБУЛЛАШУ** II *и.* 1) Аерылышу алдыннан исәнлек-саулык теләшү гадәте

2) Аерылышу күренеше; аерылышу мизгеле. *[Дамирә] Миңа да әмер бирә: – Син ачарсың, абыкаем, Саубуллашу кичәсен. Һәм үзең белеп шунда, Экспромтом гына Берәр сүз дә нитәрсең.* Х.Туфан. *Тәгин углан Албуга әнисе өендә туганнарын, ил агаларын, аксакалларны, йөзбашларын, унбашларын җыеп, үзенең саубуллашу сүзләрен әйтте.* Н.Фәттах. *Мин, Вәли абыйны саубуллашу чәенә дәшәргә дип, алар тирәсенә төшкән идем.* Г.Бәширов

**САУГА** *и. иск.* Ганимәттән бүләк итеп бирелә торган әйбер яки әсир. *Батырдан – сауга, мәргәннән – сыралкы.* Мәкаль

**САУГАТ** *и. иск.* **сауга**. *Как сөяген каерып, Куйдай итеп маерып, Ир Капланны өереп, Туктамыш хан кашына Саугатка алып китерде.* Дастан. *Саугатлар гына яшәсә, без аны «Коллар бистәсе» дип атап йөртер идек.* В.Имамов

**САУГЫЧ** *с.* **1.** Саву (*1 мәгъ.*) өчен хезмәт итә торган. *Саугыч аппарат*

**2.** *и. мәгъ.* Саву җайланмасы, аппараты. *Электр саугыч*

**САУДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **саву**. *Чирләгән чакта сыерны күршеләрдән саудыру*

2) Саугыч (**2.**) ярдәмендә саву. *Алар, чират торып, тәүлеккә өч тапкыр роботтан саудыра.* Безнең гәҗит

3) Саварга ирек бирү, карышмау (савым терлек тур.). *Кәҗә, саудырмаска теләсә дә, бик ямьсез тавыш берләп: «Минем сөтемне урлыйлар, минем сөтемне талыйлар, әби, кил!» – дигән кеби кычкыруыннан туктамады.* Г.Исхакый. *Марта да кем туры килсә шуннан саудыра торган булып чыкты.* Р.Гаязетдин

4) Сөт бирү, ташланмаган булу (савым терлек тур.). *Сөте көннән-көн кими барса да, сыерыбыз саудыра, бакчадагы бәрәңгебез дә бетеп житмәгән иде.* М.Әмир. – *Әлегә 23 биябез саудыра, көненә 80 литрдан артыграк сөт бирәләр, – ди әлеге хуҗалыкта шулай ук 20 елдан артык баш зоотехник булып эшләүче Раян Морзабаев.* Кызыл таң

**Саудыра башлау** Саудырырга тотыну. *Сыерларның берсе ташлатса, икенчесе саудыра башлый.* Кызыл таң

**Саудырып йөрү** Гел, һәрвакыт саудыру. *Әгәр ут булмыйча сыерларын трактор белән саудырып йөрсә, пычрактан малларга азык кертер юлы булмаса, ссуда бирелмәсә, озак эшли алырмы фермер?* Безнең гәҗит

**Саудырып ташлау** Тиз арада саудыру. *«Тимер савымчы» башта җиленне юдыра, массажлый, имчәк төбендәге сөтне саудырып ташлый.* Саба таңнары

**Саудырып утыру** Һәрвакыт һәм дәвамлы саудыру. *Ә Россия колхоз сыеры түгел, кем җитте шуңардан саудырып утырып булмас шул...* Шәһри Казан

**САУ-ИМИН** *с. к.* **сау-сәламәт**. *Иң зур бәхет – сәламәтлек. Сау-имин чакта белмисең генә.* Ш.Галиев

**САУЛАНУ** *ф. сир. к.* **савыгу**. *Саулангач, исән-сау йөрсә, кайчан булса да үзе кайтыр, диделәр [Гәрәйне].* Г.Мөхәммәтшин

**САУЛЫК** I *и.* Сау булу, сәламәтлек; чирсез-авырусыз булу. *Саулыкларын сорашудан алда Сулар сузам ашыгып әлгәре.* Х.Туфан. *Газзәне әйтәм, гүзәлләрнең гүзәле булып та утырып калды, ә синең саулыгың да ташка үлчим генә бит әле.* Г.Галиева

◊ **Саулыкка туймау** Сәламәтлек канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмау. *Вәзир дә бер дә аптырамыйча: «Мин Иранда тудым, хезмәтем вәзирлек иде; мин үлгәнче саулыкка туя алмадым; шул сәбәпле хөкемнәрне, эшләрне янымдагы секретарьга тапшырдым», – диде.* Г.Тукай. *1960 елгы улым Шәйдулла да саулыкка туймый: анда югары кан басымы, йөрәк, хатыны Әлфия дә гел авырый, больница юлыннан кайтып кермиләр...* Ф.Бәйрәмова.

**Саулык какшау** Сәламәтлек начарлану, начар якка үзгәрү. *Тукай килгән вакытларда җәмгыятьнең директор-распорядителе саналса да, саулыгы какшау сәбәпле, җитәкчелек эшеннән читкәрәк китеп, эшне энесе Якупка тапшырган була.* И.Нуруллин. *Минем дә бер туганым, саулыгы какшап, быел хастаханә юлын шактый таптагач, башка беркайчан да дарудан баш тартмаячакмын, дигән ныклы фикергә килде.* Ватаным Татарстан

**САУЛЫК** II *с.* Ана җенестән, теше (бәрән тур.). – *Хәзер сарыкларның баш саны 150 гә җитте: 80 сарык, 40 лап саулык бәрән, калганнары – тәкәләр, – ди фермер.* Әгерже хәбәрләре

**2.** *и. мәгъ.* Ана җенестән, теше бәрән. *Аларның сарыклары да ике саулык, бер тәкә бәрәнләсә, безнекеләр дә ике тәкә, бер саулык бәрәнлиләр.* А.Хәлим

**САУЛЫК-ИСӘНЛЕК** *җый. и. к.* **саулык-сәламәтлек**. *Солдат электән дә аларда булганга күрә, кергәч тә үзен иркен генә тотып, карчык һәм Газизә белән үзләрчә генә саулык-исәнлек сорашкач, өстәл янына килеп утырды.* Ш.Камал

**САУЛЫК-СӘЛАМӘТЛЕК** *җый. и.* Исәнлек-саулык, тазалык; авыру булмау. *Икебез дә бер үк вакытта, бер үк авыруны баштан кичергән, бергә, бер палатада яткан кешеләр булганлыктан, саулык-сәламәтлек турында гомумән сораштырмыйча, иң башлап «мотор» белән кызыксындык.* Г.Әпсә-

ләмов. *Ирләр бер шешәне бау белән кое төбенә төшергәннәр икән, шуны тартып чыгардылар һәм, --- саулык-сәламәтлек теләп, эчеп тә куйдылар.* А.Гыйләҗев

**СА́УНА** *и. фин* Парлану ягында кайнар коры һава һәм салкын сулы бассейны булган мунча. *– Сауна – шәп нәрсә, тиз айныта, – дип көлде йорт хуҗасы, һәм алар икесе ике тарафка – ике басмага таба йөзеп киттеләр.* Р.Мирхәйдәров. *Загста язылышкач, без икәү саунага керербез.* Р.Батулла. *– Мин саунага керәм, яме? – Сандугач, толымнарыннан чупыр-чупыр су агызып, баскычтан менде.* Н.Гыйматдинова

**САУНДТРЕК** *и. ингл. махс.* Кинофильм, телетапшыру, компьютер уены һ.б.ш. барган чакта уйнатыла торган көй (яки җыр) һәм шундый көйләрдән төзелгән музыкаль альбом. *Радик Сәлимов спектакль өчен махсус иҗат иткән көйләр – саундтреклар сыман: бүген үк сайтка эл дә тамашачыны «кармакка эләктер».* Сәхнә

**САУРЫ** *и. к.* **саурый**. *Ат саурысы селкенеп, Сан сөяген тартканда Селкенмәде Кыпчак би.* Дастан. *Аның [читекнең] саурысы синең апаңның намазлык чигә торган үрнәге кебек чәчәкле була.* Г.Исхакый. *[Әтиләре] ике улына да пардан куныч кырыена кызыл сәхтиян тоткан, үкчәсенә яшел саурысалган читек алдырды.* М.Гали

**САУРЫЙ** *и.* **1.** 1) *к.* **савыр**

2) Савыр күне

**2.** *с. мәгъ.* Шундый күннән яки шуны кушып эшләнгән. *Җиһаннарда егетнең солтаны, – Саурый үкчә – болгар олтаны.* Җыр. *Саурый читек, чуклы башмак, вак-вак атлап яндыра; Яка сапкан, энҗе таккан, бак, үзен зурга [куя].* М.Укмасый. *Болгар кызлары, биек үкчәле саурый кәвешләрен киеп, озын койрыклы ак калфакларының чукларын табаннарына кадәр салындырып, ак ефәк күлмәкләренең чабуын бераз тотыбрак, Тойгыга хәзерләнгән сарайга таба агылалар, туктап-туктап җырлыйлар, шатлыклар изһар итәләр иде.* Н.Думави

**САУРЫЙЛЫ** *с.* Саурый кушып эшләнгән. *[Гыйльметдиннең] өстендә буй-буй чапан. Аякларында саурыйлы читек.* К.Нәҗми

**САУРЫЛЫ** *с. к.* **саурыйлы**. *[Әтиләре] ике улына да пардан --- саурылы үкчәле шыгырдавыклы кәвеш алдырды.* М.Гали

**САУ-СӘЛАМӘТ** *с.* **1.** Исән-сау, чирле түгел. *Хәзер исә шул дәвалануларының шифасын күргәч, ул үзен сау-сәламәт кеше исәпләп, яңадан эшкә – һәрдаим җаны-тәне белән онытылган изге эшенә чумды.* А.Расих. *Ул бит яшь, сау-сәламәт, эшлим дисә – кулыннан эш килә!* Г.Ахунов

**2.** *рәв. мәгъ.* Авырмыйча, сәламәт булып. *Моннан соңгы алгы язларга да Сау-сәламәт җитә алыгыз.* Х.Туфан

**САУСЫЗ** *с.* Саулыгы начар, сәламәт түгел. *Әти бу вакытта картаеп өлгергән, җитмәсә тагын саусыз да иде.* Ф.Хөсни. *Мин, карчык әйткән сүзләргә көлемсерәп: «Әби, мин шушылай саусыз хәлемдә кияүгә чыгаммыни?» – дип сорадым.* Ватаным Татарстан

**САУСЫЗЛЫК** *и.* 1) Саусыз булу, сәламәт булмау, чирлелек. *Профессорның саусызлыгы, артык картаеп киткәнлеге, озак күрми торгангамы, Заһитка бик ачык сизелде.* А.Расих. *Иң куркынычы – халыкның сәламәтлеге, дөресрәге, соңгы чиккә килеп җиткән саусызлыгы.* Татарстан яшьләре

2) Авыру, чир, хасталык. *Еш кына уйланасың да тагын бер кат таң калып куясың: кечкенәдән үк кимлекхурлыклар күреп үскән япа-ятим, саусызлыктан интеккән күбәләк җан --- ничек итеп бөтен бер халыкның рухи биеклеген билгеләүче затка әйләнә алды икән?* Р.Фәйзуллин

**САФ** I *и. гар.* 1) Бер сызык буенча һәм тигез ара калдырып урнашкан бер иш әйберләр яки кешеләр төркеме; рәт. *Сөңгечеләр, һәркем үз урынын белеп, бер сафка тезелде.* Н.Фәттах. *Эткол урамыннан мәчеткә таба сафларга тезелгән шактый халык, яшел һәм кызыл байраклар күтәреп, эреп боткадай саргайган карны ера-ера узып баралар.* Ә.Еники. *Карчык-корчык, бу олы, изге эшне күрүдән мәхрүм калмаска тырышып, бер читтәрәк чуар саф булып тезелешеп карап тора.* А.Гыйләҗев

2) Театр, кино һ.б.ш. тамаша залларында бер-бер артлы урнашкан утыру урыннары. *Айсылу арттагырак сафлардан кемнедер күзләре белән эзләп тапты.* Г.Бәширов. *Алгы сафта тезләренә утырган Хафиз – Әхмәт бабайның энесе – түзеп кала алмады.* Ф.Яхин

3) *кит.* Даирә, коллектив; төркем, берлек. *Каюм Насыйри бабабыз әнә, фигыльләр буенча гына фикер йөртсә дә, татар теленең дөньядагы иң бай телләр сафында торырга тиешлеген әйткән.* С.Поварисов. *Әйтик, [Н.Гыйматдинованың] өч әсәре театр сәхнәсенә менгән язучы китапларын укучылар сафын театр тамашачылары саны белән дә киңәйтте.* А.Юнысова

◊ **Сафка басу** 1) Башкалар дәрәҗәсенә күтәрелеп, алар белән бергә эшхәрәкәт итә башлау. *Без аның тиз арада савыгып, яңадан сафка басуын көтәбез.* И.Салахов. *Рус, Европа мәдәниятен белү аңа әдәбият мәйданының алдынгылары сафына басарга ярдәм иткән.* Р.Рахман; 2) Эшли башлау, эксплуатациягә тапшырылу (төзелеш объектлары һ.б.ш. тур.). *Ауганнарны алмаштырган сыман, Сафка басты азмы романың!* Х.Туфан. *Егерме сигезенче елны беренче фабрика ачылса, икеөч елдан инде аның икенче, өченче, хәтта дүртенче фабрикалары да сафка басты.* Ә.Еники. **Сафтан чыгу** 1) Имгәнеп, авырып яки бүтән сәбәптән эшкә яраксыз булып калу. *Ләкин бу зыялылар берәм-берәм сафтан чыгып, Сталин җәһәннәменә озатыла башлагач, кызыл авызлар какофониясе дәррәү көчәеп китә.* Р.Әмирхан; 2) Бозылып, ватылып һ.б.ш. сәбәпләр аркасында яраксыз хәлгә килү. *Берәүнең дә эшкә кулы бармый, өстәвенә электр кабеле сафтан чыгып, барлык аппаратура туктап калды.* А.Тимергалин. *Кан басымым да күтәрелгән бугай: йөрәк, бер цилиндры сафтан чыккан мотор сыман, озын-озын тәнәфесләр ясап тибә.* Ф.Шәфигуллин

**САФ** II *с. гар.* 1) Чиста, ару, пычранмаган, болганмаган. *Ермак дигән елганы кичәбез. Яшькелт фирүзә төсле су, көчле агым, саф су.* Р.Батулла. *Урман-*

*таулар артында туган яклар кала, яшел болыннар, саф сулы елгалар кала.* Ф.Бәйрәмова

2) Тапланып яки тузанланып пычранмаган, керләнмәгән. *Язда гына булып ала торган кыска гомерле саф яшеллеккә күмелеп утырган сихри бер көнне Әскәр хатыны белән улын роддомнан алып кайтты.* А.Гыйләҗев. *Бар дөнья саф яшеллеккә күмелгән, җиһанны бизисе гөлләр әле бөредә генә иде.* Р.Габделхакова

3) Бөркү түгел, җиләс һәм тузансыз; сәрин. *Язның кичке һавасы артык суык та, җылы да түгел. Шундый саф, сулаган саен йөрәккә җиңеллек бирә...* Ә.Еники. – *Күрсәтәм, – диде Фатих. – Кәгазьләрегездән бераз арынып, саф һава сулап кайтырсыз.* Ф.Яруллин. *Һәр тарафтагы иртәнге саф һава сулышларны иркенәйтә, бөтен җанны иркәли.* Г.Галиева

4) Болытсыз, томансыз, зәңгәрлегенең җетелеге ап-ачык күренеп торган (күк йөзе тур.). *Минем бәхеткә, көн бик аяз, күк саф вә ачык булып, кояш та төшлеккә таба акрын гына текәп бара иде.* Г.Ибраһимов. *Гәрәбәдәй саргылт озын толымнар, саф күк йөзе кебек зәңгәр күзләр, алсу, тулы иреннәр һәм аккош канаты шикелле ап-ак куллар.* В.Имамов

5) Салкынча һәм йомшак; сәрин (җил тур.). *Җил япкан тәрәзәне тагын барып ачты Нурулла, тыштан саф җил өрелеп керде.* А.Гыйләҗев. *Җаныңа сал әтиеңнең илен, Әниеңнең телен; Туган якның көнен, җиләс төнен, Иртәнге саф җилен.* Г.Афзал. *Кыйблабыздан искән саф җилләрнең Тоймый калдык җанны назлаганын.* Ч.Мусин

6) Катнашмасыз, кушылмасыз, бер иштән, бер төрдән генә торган (химик элементлар, матдәләр, минераллар тур.). *Тигез итеп шомартылган, югарыга таба нечкәрә барган карагай баганаларның өчесе дә астан өскә чаклы саф алтын белән тышланган.* Н.Фәттах. *Кипр кызларының милли киеме саф киндер күлмәк, киндер алъяпкыч икән.* М.Мәһдиев. *Тәсбих төймәләренең саф алтыннан икәнлеге ерактан ук күренеп тора иде.* Р.Батулла

7) Бер генә ишле, башка төсләр яки төсмерләр катнашмаган (төсләр тур.). *Шушы саф зәңгәрлектә кыр казлары озын муеннарын сузып очып баралар.* Г.Әпсәләмов. *Язның саф һавасында саф төсләр җете ачыкланып, яңарып күренә.* Ш.Галиев

8) Башка төрләр яки төрчәләр катнашмаган (нәсел, токым тур.). *[Сыерлар] Сөтне чиләкләп актара торган нәселдән, саф холмогор токымыннан кирәк.* Б.Камалов

9) Башка нәсел каны катнашмаган, кан ягыннан башка катлам вәкилләре белән аралашмаган (кешеләр тур.). *Башка телгә табынулар чоры Читкә этте сине – пакь җанымны, «Телләр авыруы» изгәндә дә Алмашмадым сине – саф канымны.* Р.Шиһапов

10) Яңа яки ял иткәннән соңгы; яңарган, арымаган (көч, дәрт, акыл һ.б.ш. тур.). *Гыйззәтуллинның саф миенә бу сүз мәңгелек булып уелып калды.* М.Мәһдиев. *Хәзер, саф акыл белән уйлаганнан соң, ул монда тагын бер шкаф куярга булды.* А.Тимергалин. *Ял итеп алдык без, Сизми дә калдык без – Ял тәмам ич! Башлар саф, тәндә көч!* Р.Миңнуллин

11) Эчкерсез, риясыз, керсез, пакь (күңел, уй, хис-теләк һ.б.ш. тур.). *Ул Кадриянең моңарчы кеше кулы тимәгән саф хатирәләренә, саф истәлекләренә пычрак атачак.* А.Гыйләҗев. *Ат караучы абзый моны аңлады күрәсең: сабыйларча саф бер елмаю белән елмаеп, әле бүген генә танышкан үсмер егетнең җилкәсенә исән кулын китереп салды.* Г.Ахунов. *Истәлек авторлары аның тыйнак холыклы, саф күңелле, тиз ышанучан булуы турында яза.* Р.Зәйдулла

12) Бозык түгел, рухи яктан тотнаклы. *Саф җаннарда гына була торган Йомшак, иркә җылылык белән, Кызлар мине урап алган иде.* Х.Туфан. *Гомумән, бозык хатыннар саф хатын-кызлар белән дус булырга омтылалар, алар әнә шундый риясыз хатыннарның беркатлы бәхетләрен күрүдән тәм табалар иде.* А.Гыйләҗев

13) Гыйффәтле; гөнаһсыз, гаепсез. *Саф кыз булып тормышын миңа багышлаган, чын ярату булмаса, язмышы белән шулай уйный алырые микән?* Г.Галиева. *Әрлә. Тиргә. Бик каты бер яман сүз әйт. Чөнки мин шуңа лаек хәзер. Мин саф түгел инде. Синең алда гөнаһлымын...* С.Поварисов. *Аларның берсе – саф кыз, икенчесе саф егет иде...* Н.Гыйматдинова

14) Чиста күңелле, намуслы, гөнаһсыз, пакь. *Ул Җиһангир алдында, әтисе Ярулланың рухы каршында саф, шәфкатьле булып калырга теләде.* Н.Хәсәнов. *Ә кыз... Яшь болан баласыдай сылу, яңа ачылган роза чәчәгедәй гүзәл, җиләк яфрагына кунган таң чыгыдай саф иде ул бер үк вакытта.* Р.Мөхәммәдиев

15) Бик ачык яңгырап, яхшы ишетелә торган (тавыш, аваз һ.б.ш. тур.). --- *ә менә бу язгы саф авазларның, тымызык тамчыларның, җылы кояш нурларының нинди уен коралларыннан чыгуын ул берничек тә аңлый алмады.* Г.Ахунов. *Күкрәк төбеннән чыга аның [Идриснең] тавышы, искиткеч йомшак: вак ташларга бәрелә-бәрелә, тамчылар чәчрәтеп аккан чишмә авазы кебек саф иде.* Х.Сарьян. *Совет поэзиясе багларында мондый саф тавыш ул замандагы «бакчачылар»ның күңеленә хуш килеп бетми, әлбәттә.* Р.Гаташ

16) Норма-кагыйдәләргә төгәл туры килә торган, дөрес (тел, сөйләм, стиль һ.б.ш. тур.). *Телебезнең саф татарчага әйләнә баруы, сүз сәнгате буларак аның нәфисләшүе, образлашуы, бизәкләргә баюы Фатихлар, Галимҗаннар заманына туры килә.* Ә.Еники. *Саф татар сүзләре яшьләргә аңлашылмый башлаган.* Н.Гыйматдинова. *Барыгызга да мәгълүм: «тәмам» – саф гарәп сүзе.* Г.Мөхәммәтшин

17) Башка стиль, жанр үзенчәлекләре катнашмаган. *Бер Роберт Әхмәтҗан гына саф лирик булып калды...* Ш.Галиев. *М.Мутиннан аермалы буларак, С.Булатов саф романтик спектакльләр кую максатын алга сөрми.* М.Арсланов

18) Барлык чигерүләрдән тыш булган, кулга тулысынча керә торган (акча, табыш һ.б.ш. тур.). --- *шәһәр базарын-*

*да итнең килосы биш сум; уртача ике йөз сиксән кило чыкса да, мең дүрт йөз сум саф акча ---.* М.Мәһдиев

**САФА** *и. гар. иск.* Рәхәтлек, ләззәт, хозурлык, кайгысызлык. *Эчүченең сафасы – кешегә салган җәфасы.* Мәкаль. – *Эшлә, эшлә, әүвәл җәфа, соңра сафа, – дип сүз кушты Хисаметдин.* М.Акъегет. *Кешенең авызыннан чыккан һәрбер сүзе җәүһәр вә хикмәт булсын, әрсезлек кыйлса, хикмәте калмас вә сүзенең сафасы булмас.* К.Насыйри

◊ **Сафа киләсез (килдегез)** «Хуш килдегез, рәхим итегез» дигән мәгънәдә сәламләү сүзе. *Хәдичә: «Хуш килдең вә сафа килдең, я Мөхәммәд, малыңыздан зарар итмәдеңезме?»* К.Насыйри. *Арабызга кунак булып тәшриф боеруыңыз безне гаять шатландырды, сезне: «Хуш килдеңез, сафа килдеңез!» – диярәк җаннан алкышлыйбыз.* Г.Исхакый. **Сафа сөрү** 1) Рәхәттә, борчусыз-гамьсез яшәү. *Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә.* Г.Тукай. *Аның өчен пәйгамбәрләр вә олуглар михнәт күрә килгәннәр, ә белексез җаһилләр зәвык вә сафалар сөрә килгәннәрдер.* Кәлилә вә Димнә; 2) Күңел ачу, ял итү. *Бу кыз берлә көлеп-уйнап тәмам атна кадәр торгач, Күңел ачкач, зәвыклангач вә күп рәхәт-сафа сөргәч, Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына, Ияртеп гаскәрен, саф-саф тезеп һәр дүрт җиһатына.* Г.Тукай. *Без мәнә дигән тормыш белән тора: көннең билгеле вакытларында тырышып эшли, аннан соң җыелышып уйный, кәеф вә сафа сөрә идек.* Ф.Әмирхан. *Үзе, чарасызлыктандыр, мөгаен, сафа сөрүгә һәвәсләнеп китте.* М.Әмирханов. **Сафа чигү** *к.* **сафа сөрү**. *Зәвык вә сафа чигеп, ике гашыйк таң яралганны белми калдылар.* М.Акъегет. *Ә фермада эшләүченең алай читләргә китеп сафа чигеп йөрергә вакыты юк, бигрәк тә җәй көннәрендә.* А.Вергазов

**САФА́РИ** *и. гар.* 1) Африкада кыргый хайваннар ауларга рөхсәт ителә торган тыюлык һәм шунда аучылык итү

2) Кыргый хайваннар яши торган милли паркларга, тыюлыкларга, кыргый табигатькә чыгу; экстремаль сәяхәт. *Ул аеруча сафари дип аталган, джипта сәяхәттән гыйбарәт булган экскурсиядән канәгать калды.* Сөембикә. *Белгечләр паркны берничә өлешкә бүлмәкче: маҗара, гаилә, гореф-гадәт һәм сафари аланнары.* Ватаным Татарстан

3) Шома материалдан туры тегелешле, кесәләре булган кием. *Искә аласыңмы Ак сафари – Ак күлмәктән мине көткәнне?!* Р.Гаташ. *Андыйларга тыныч төсләрдәге сафари яки спорт стилендәге сарафаннар килешә төшәр.* Ватаным Татарстан

**САФӘР** *и. гар.* Мөселман календаренда икенче айның исеме

**САФДИЛ** *и. фар. иск.* Саф күңелле, эчкерсез. *Бәлки дә, кайбер тәҗрибәсез сафдил яшьләрне җирле шовинистлык рухында тәрбия итеп, зур тартыш көннәрендә безнең берлек сафыбызны бүлгәләргә, вакларга --- тырышачаклардыр.* Г.Исхакый

**САФИР** *и. к.* **сапфир**. *Сафир кашлы йөзек*

**САФЛАНДЫРГЫЧ** *с.* Чиста, саф итә торган; сафлык бирә торган. *Әле кайчан гына бөтен дөньяны күңел кайтаргыч караңгылыкка ураган бу ябышкак күләгәне кысрыклаучы көч яңа туган кояштай сафландыргыч яктылыктан гыйбарәт иде.* А.Вергазов. *Һималай тауларының сафландыргыч һәм затландыргыч көче тәэсиреннән киләдер бу.* Кызыл таң

**САФЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Чистарту, саф итү. *Битләрен сафландырды, чәчләрен төзәтте.* Р.Шәфигуллин. *Су тукландырган һәм тормыш-көнкүрештә ярдәм иткән, сафландырган һәм дәвалаган.* Татарстан чишмәләре

2) Тондыру, чиста, саф, ару итү (суны һ.б.ш.).

3) Тузаннан, бөркүлектән, төрле исләрдән арындырып, җиллләтеп саф итү (бүлмәне, һаваны). *Үзәнгә, туфракның үзенә төшеп җитә алмыйча суынган бу нурлар, инде түбәннән күтәрелеп оеган дым, сусыл тын белән очрашып, һаваны сафландырганнан-сафландыра бара.* А.Хәлим. --- *мәсләгеннән чигенми торган язучыларны диалогка чакыруы да, миңа калса, аның театраль мохитне яңартырга, һавасын сафландырырга омтылуы белән бәйле иде.* Р.Зәйдулла

4) Нәселне, токымны торгызу, яхшырту. – *Нинди нәсел дип тә булмый аларны [сыерларны], борыннан килгән вак нәсел дә, колхоз вакытында алынган кайбер эре нәселләр дә сугыш вакытында буталып беткәннәр. – Ярамый болай, – ди Нургали, эченнән генә көрсенеп, – нәселне тазартырга, сафландырырга кирәк.* Ә.Еники

5) *дини* Изгеләндерү. *Госам алар янындагы ерымнардан ага торган суны сафландырды, Изге утны кабызып, күмәк кеше катнашында гыйбадәт кылып, яңа храмга фатиха бирде.* Б.Рафиков. *Шул ук төнне храмның настоятеле Роман атакай Урыссуның Изге Николай храмында суны сафландырды.* Ютазы таңы

6) Башны ял иттерү. *Мәнә шушы каен себеркесе белән азмы-күпме башымны сафландырам...* Р.Низамиев. *Талгын искән җил башны сафландыра, күңелдәге төеннәрне чишеп, җанны авыр тойгылардан арындыра.* Г.Госман

7) Күңелне, рухны тискәре хисләрдән, буталчык фикерләрдән арындыру. *Беренче мәхәббәт, беренче язгы чәчәкләр, беренче бала һәм беренче булган тагын бүтән нәрсәләр безнең җаннарны әллә ничек сафландыра, биегәйтә бит.* Р.Фәйзуллин. *Әлеге эшкә халыкны әзерләргә кереште: җәмгыятьне тазарту-сафландыру турында да, акылы зәгыйфьләнгән иптәшләрне дәвалау өчен махсус дәваханәләргә озату хакында да бик тәмләп сөйләде [Кызыл Хаким].* М.Кәбиров

8) Тел, сөйләм, стильне нормакагыйдәләргә туры килмәгән күренешләрдән арындыру. *Мин бик яхшы аңлыйм: телне сафландыру мәсьәләсе борчый сезне.* Ватаным Татарстан

**Сафландыра бару** Торган саен ныграк сафландыру. *Шириннең олы мәхәббәте Хөсрәүнең табигатен сафландыра бара, аның мәсләксез тормышына мәгънә кертә, кылган һәм кыласы эшгамәлләре өчен вөҗдан җаваплылыгын арттыра.* Х.Миңнегулов. *Рәхәт, чөнки синең аклыгыңда, пакьлегеңдә коену җанымны сафландыра барганлыгын бөтен барлыгым белән тоеп йөрим.* Ф.Яруллин

**Сафландыра башлау** Сафландырырга тотыну. *Шундыйларны алып, иманлы балалар үрчетеп, милләтне сафландыра башларга вакыт безгә!* Казан утлары

**Сафландыра килү** Күптәннән бирле даими рәвештә сафландыру

**Сафландыра төшү** Тагын бераз сафландыру, күбрәк сафландыру. *Күңелле мәшәкатьләрдән соң Фатыйма апабыз душта коенып, тәнен һәм җанын тагын да сафландыра төште.* Ә.Баян

**Сафландырып алу** Тиз арада, тиз генә сафландыру. *Үзеңнең бала чагыңа кайту кайвакыт бик рәхәт булып, күңелне сафландырып ала.* Г.Бәширов. *Иҗатка кузгату өчен, ачу-нәфрәт тә кирәк. Яратуны җилләтеп, сафландырып алу өчен кирәк.* Ш.Галиев

**Сафландырып бетерү** Барысын да, тулысынча сафландыру

**Сафландырып җибәрү** Тиз арада сафландыру. *Җанны сафландырып җибәрә, күңелгә – мәгънә, уеңа – киңлек, хисләреңә тирәнлек килә мондый кеше иҗатыннан.* Ш.Галиев. *--- бер уңайдан медпунктны да җыештырып, идәнен юып, һавасын сафландырып җибәрде.* Ә.Сәлах

**Сафландырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә сафландыру. *Ихласлык ихлас шәхескә тормышта күп кыенлыклар, бәлаләр китерсә дә, кешеләр яшәешен һәрдаим балкытып, җемелдәтеп, үзара мөнәсәбәтләр атмосферасын пакьләп, сафландырып торучы садә җил, изге нур ул!* Ф.Дунай

**САФЛАНУ** I *ф.* Сафка яки сафларга тезелү. *Хәбәр юк ханга, беркөнне әтәч тавышлана тагын, Менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын.* Г.Тукай. *[Хәнәфи:] Сафланыгыз, сафлан.* Аманулла

**САФЛАНУ** II *ф.* 1) Чистару, ят нәрсәләрдән арыну, саф булып калу. *Бервакыт ул [җир асты байлыгы] чыгарыла, сафлана, эшләнә, аннан акчалар сугалар, шулай итеп, ул бөтен дөньяга падиша була.* Җ.Вәлиди. *Ул [сәнгать] да халык арасыннан килеп чыккан йөзләрчә талант ияләре хисабына байый. Идел кебек тирәнәя, киңәя, сафлана.* Л.Шагыйрьҗан. *Ниһаять, беразга гына булса да, бүгенге шалтыр-шолтыр такмаклардан саңгыраулана башлаган колаклар ял итеп, күгәрә башлаган күңелләр сафланыр, дип сөендем.* Т.Миңнуллин

2) Болганудан туктап, тонып чистару (су тур.). *Су да гел болганчык тормый, Бер чистара, сафлана.* А.Хәсәнов

3) Тузаннан, төрле исләрдән, бөркүлектән арыну, җиләсләнү (бүлмә, һава тур.). *Җыештырып, тузанын сөртеп чыгаргач, өй һавасы сафлана, сулыш киңәя.* А.Гыйләҗев. *Назлы җилләр сыйпап үтә, Сафлана һавалар да.* Р.Шәехова. *Һава чистарды, сафланды.* Д.Гайнетдинова

4) Болыттан, тузаннан арынып ачылу (күк йөзе тур.). *Җәяүле бураннар юашлана, күк йөзе сафлана, зәңгәрләнә барган кебек.* С.Шәрипов

5) Бераз салкынчалану, сәринләнү (җил тур.)

6) Ял итү, хәл алу (баш, тән тур.). *Чишенәсең, Бөтен тәнне Салкын кар белән уасың – Җаның, тәннәрең сафлана, Гүя яңадан туасың.* Х.Касыйм. *Себерке белән чабынып алгач, тән сафлана, җан тынычлана, күңелгә сихәт иңә.* Р.Мулланурова

7) Тискәре хисләр, буталчык яки начар уйлар, бозык ниятләр һ.б.ш.дан арыну. *Ике җанның берләшү, серләшү һәм сафлану моменты иде бу.* Х.Камалов. *Елау – кешенең сафлануы, чистарынып калуы.* Ш.Галиев. *Чыкса да кем авызыннан, Нахак сүз ул агу сыман. Шуңа аннан сакланам мин, Хак сүз белән сафланам мин.* Х.Халиков

8) Эчкерсезләнү, риясызга әйләнү, пакьләнү. *Ул чыганакка килгән кешенең дә җаны чистара, күңеле сафлана.* Ш.Галиев. *Элегрәк кышка керсәң, Дөнья аклана иде. Шуңа ияреп, бар кешенең Күңеле сафлана иде.* К.Булатова. *– Күңелеңнең чистаруы, сафлануы бу, – дип аңлатты Баһадур.* Л.Гыймадиева

9) Ачык яңгырый башлау (аваз, тавыш тур.). *Минем тавышым сафланыр, матурланыр.* М.Максуд

10) Тел, сөйләм, стиль турында: норма-кагыйдәләргә туры килмәгән күренешләрдән арыну. *Әдәби телебез сафлана, чарлана, гарәпчәлектән шактый арына, ләкин кирәк кадәресе сакланып кала да.* Ә.Еники. *Сәләтле егетнең теле тагын да ныграк шомара, сафлана, матурлана.* З.Зәйнуллин

**Сафлана бару** Торган саен ныграк сафлану. *Бу концертта безнең үзебезнең яхшыра-сафлана баруыбызны тоеп утыру бик куанычлы иде.* Ә.Еники. *Әйтерсең сусаудан әлсерәп кипкән һәр күзәнәге сугарылып туена, сафлана бара...* Г.Әдһәм

**Сафлана башлау** Сафлану билгеләре сизелү. *Киресенчә, ирек җилләре исеп, һавалар сафлана башлады.* Р.Кәрами

**Сафлана төшү** Тагын да сафлану; бераз сафлану. *Бер көнгә без яңадан мәктәп елларына, балачакка кайттык, күңелләребез шул вакытның истәлекләре белән яңарды, яшәрде, сафлана төште сыман.* Ф.Латыйфи. *Кичә генә явып үткән яңгырдан соң һава тагын да сафлана төшкән.* Р.Шәмсетдинова

**Сафланып бетү** Тәмам сафлану

**Сафланып калу**Ниндидер тәэсирдән соң сафлану. *Төнлә шик-шөбһәләр тудырган һава бөтенләй үзгәргән, аз гына яңгыр сибәләп киткән, җир дә, күк тә сафланып калганнар.* А.Гыйләҗев. *Минем өчен җәйнең иң гүзәл мизгеле балачакта да, хәзер дә берДәнбер: күкрәп-яшенләп яуган яңгырдан соң ачылып, сафланып калган һава, юынып, чистарынып киткән табигать.* Х.Ширмән

**Сафланып китү** Кинәт сафлану, нәрсәдер тәэсирендә сафлану. *Ләкин гомумән түрәлектән түгел, ә түрәлекнең аерым бер, аеруча ләззәтле бер мизгелендә яшәреп, сафланып китәләр алар.* М.Мәһдиев. *Ах, сөеклем, яңгырдан соң бар табигать яшәреп, сафланып киткән.* Аманулла

**САФЛА́У** *ф. к.* **сафландыру**. *--- тарихның хосусый милек сазлыгына батып, шуның идеологиясеннән миләрен сафлый алмаган бәндәләрнең --- яңа дәверләрне инкяр кыйлып маташулары да шул дәрәҗәдәге хаклы бер эштер.* Г.Ибраһимов. *Һәркемгә бер үк теләк, һәркемгә бер үк бурыч: Тәнең, җаныңны сафла, Чыныккач сынмый корыч.* Б.Рәхимова

**САФЛОР** *и. ингл. бот.* Катлаулы чәчәклеләр семьялыгыннан, Европаның, Азиянең кайбер илләрендә үстерелә торган бер яки күпьеллык үсемлек; косметологиядә, медицинада, кулинариядә һәм аеруча буяу ясау өчен кулланыла. *Татарстанда бакчаларда үстерелә торган артишок трибасына кергән үсемлекләр бар: чын артишок затлы яшелчәдән санала, буяу сафлоры – кызыл һәм сары буяу чыганагы, сафлорсыман левзея, яки марал тамыры – кыйммәтле дару үләне.* Ботаника. *Бу гөл Кавказ илләрендә тәмләткеч (шафран яки сафлор) һәм табигый буягыч матдә буларак та файдаланыла.* Туган як

**САФЛЫ** *с.* Сафка (I) яки сафларга тезелгән. *Сафлы колонна күздән югалгач кына сүзен башлады Әмирхан.* Ватаным Татарстан

**САФЛЫК** *и.* 1) Саф (II) булу сыйфаты яки хәле. *Газеталарда татар теле, аның сафлыгы, имла мәсьәләләре хакында мәкаләләр еш кына басыла башлады.* А.Расих. *Табигатьнең шушы матурлыгына, сафлыгына сокланып, талпына-талпына мәдхия җырлаган тургайлар тавышы күңелләрне сихри наз белән күмә.* Г.Галиева. *Мәгъҗән теленең сафлыгына, чын төрки аһәңнең яңгырашына шаккатасың.* Р.Зәйдулла

2) Эчкерсезлек, чиста күңеллелек, риясызлык, намуслылык. *Әмма үзе семьяда гадел һәм тугры булгач, Идрис әле кешеләрдә бары тик сафлык, яхшылык кына күрә ала иде.* А.Гыйләҗев. *Аннары алар бер-берсенә сыенып, яшьлекнең эчкерсез сафлыгы һәм ышанучан сабыйлыгы белән кушылган тойгыларыннан башлары әйләнеп, исереп, дөньяларын онытып утырдылар.* Г.Ахунов

3) Гыйффәтлелек. *Кызлык сафлыгын җуюю әнә шул тимерчегә кияүгә чыкканда исенә төште дә бит, тик гыйффәтлелек кызларда ике булмый шул.* Ә.Салах. *Кызлар сафлыгы – дөньядагы иң чиста нәрсә.* Р.Галиуллин

**САФЛЫ́-САФЛЫ** *с.* Күп рәтләргә, колонналарга тезелгән, сафлар рәвешендәге. *Сафлы-сафлы отрядлар*

**САФРАНИН** *и. гар. тех.* Чыдамлыгы белән аерылып тора торган куе кызыл буягыч; зәгъфран буявы

**САФСАТА** *и. гар.* 1) Гадәттә артык озын, ләкин әһәмиятсез, кирәксез яки буш, мәгънәсез сүз, сөйләм, язма, әсәр һ.б. *Әгәр нефтьчеләр, корыч коючылар, --- син алганның яртысын гына ала торган гади кешеләр һәр сафсата сүзеңнең йөзәр сумга төшкәнен белсәләр, сине өзгәләп ташларлар иде.* А.Гыйләҗев. *Зәйнәпнең әлеге сафсатасы артык урынсыз, мәгънәсез булып тоелды аңа.* Х.Ибраһим

2) Ялган сүз, хәбәр, уйдырма. *Ялган акчалар төсле буш сүзләр, Михаил Петрович. Сафсата.* А.Гыйләҗев. *«Капкасы шыгырдап ачылды» диелгәнме? Бу бит сафсата, җәмәгать!* Д.Гыйсметдинов. *Үзең чыгаргансыңдыр әле бу сафсатаны...* Г.Галиева

3) Хурлау, тиргәү сүзе. *[Ситдыйк хәзрәт:] Җә, сафсата, укы!* Г.Исхакый. *Ә, әйе, менә син, сафсата, шуны да белмә, имеш: чәй бит ул – бик нечкә, бик нәзберек эчемлек, ул сиңа хәмермазар түгел, ис-косны яратмый.* Г.Ахунов. *Соңыннан да Габделхәмит абзыйга бер сүз юк: «Һай, сафсата, яндырып үтерә яздың ич!» – дигән дә шуның белән эш тәмам.* Г.Рәхим

◊ **Сафсата сату** Юк-бар сөйләү; кирәксез сүз сөйләү. *Кеше әнә нинди чиккә җиткән: Газраил бугазыннан эләктергән мәлдәгедәй тын ала, ә ул тану-танымау турында сафсата сата.* С.Поварисов. *Халыклар арасындагы дуслык турында, патриотизм хакында берәү дә сафсата сатмый.* Т.Галиуллин. *Синең белән сафсата сатарга җыенмыйм.* Р.Зәйдулла. **Сафсата чәйнәү** *к.* **сафсата сату**. *Әнә анда бик үк оста да укытмасыннар, яшь гомернең байтак вакыты кирәкмәгән сафсата чәйнәүгә дә әрәм булсын.* Г.Бәширов. *Шуларның сафсата чәйнәвен тыңлап туйгач, кинәт кенә тамагым ачып китте.* Ф.Баттал

**САФСАТАЧЫ** *и.* Сафсата сөйләүче, сафсата сатучы. *Шәһәр кышкысын салды. Селәгәен тыймый кар кере. Тагын да яз. Хәтерләтә салкын, аңгыра, сафсатачы юнкерны.* Р.Харис

**СА́Ф-САФ** *рәв.* Рәт-рәт булып. *Саф-саф тезелгән халык*

**САФТАШ** *и.* 1) Бер сафта булучы

2) Бер үк уй-хыяллар, максатлар белән, бер юлдан баручы. *Маннур, минем сафташым буларак, шуны искә алырга тиеш иде.* Х.Туфан. *Яңа гына сугыш утында булып, кешеләрне кискен аерылып торган ике төркемдә (дошман яки сафташ) танып белергә өйрәнгән яшь кешегә катлаулы яңа чынбарлыкны үзләштерү ансат булмый, әлбәттә.* Н.Хисамов

**САФУРА** *и. гар.* Дини мифологиядән кергән, усал хатын буларак күзалланган персонаж

◊ **Сафура бураннары кубару** Тавыш чыгару, әрләшү, кычкырышу. *Хатыным күрмәсен, яңадан Сафура бураннары кубармасын, ди-ди, табылган берсен унитазга салып агызам.* Ф.Баттал. **Сафура бураннары кубу** Тавыш чыгу, гауга кубу; шау-шу чыгу. *Алар килсә, монда бөтенләй Сафура бураннары куба!* Г.Камал. *Алдан ук белеп тордым өйдә Сафура бураннары кубасын.* Г.Госман. **Сафура бураннары куптару** *к.* **сафура бураннары кубару**. *Менә бу юлы тагын Сафура бураннары куптарды.* Г.Сабитов. **Сафура бураннары уйнату** *к.* **сафура бураннары кубару**. *Сафура бураннары уйнатса да, Ярулла бабай хатынына кул күтәрми, сукмый, тиз кайтып төшә.* Т.Галиуллин

**САФЬЯН** *и. фар. к.* **сәхтиян**. *Болгар осталары теккән сафьян итек-читекләрне себер татарлары мактый-мактый кигән.* С.Поварисов. – *Мин үзем, бөек хан, мин үзем!.. – диде хәйләкәр Калита һәм, идәнгә чүгәләп, Үзбәк ханның сафьян читек очларын яларга үрмәләп килә башлады.* Р.Вәли

**САХАБӘ** *и. гар.* Мөхәммәд пәйгамбәрне күргән һәм аның динен кабул иткән мөселман, әсхаб. *Гыйрфан мөхикъ (гадел) сахабәгә әйләнде.* С.Поварисов. *Көннәрнең берендә, бу сахабәнең йөкле хатыны унынчы ае белән йөри башлаганда, үзе чиләк алып суга китте.* Гыйбрәтле хикәятләр

**САХАРА́ЗА** *и. гр. хим.* Сахарозаны глюкозага һәм фруктозага тарката торган фермент

**САХАРИДЛАР** *и. күпл. гр. хим.* Гидролиз нәтиҗәсендә берничә моносахаридка таркала торган углеводлар,

органик кушылмалар классы. *Сахаридлар, углеводлар – табигый органик матдәләр берләштергән бер зур классның гомум атамасы.* Мәгариф

**САХАРИН** *и. нем.* Шикәрдән 500 мәртәбә татлырак, организмда үзләштерелми торган ак порошок хәлендәге татлы матдә, шикәр суррогаты. *Карчык сүтеп карады да аптырап калды. Ике төймә сахарин!* Г.Әпсәләмов. *Кайсы аяк киеме табып бирә, кайсы – күлмәк-ыштан я берәр кисәк сахарин (чәйтәмләткеч), кайсы китап, кәгазь, газета яки башка кирәкле әйбер юнәтә.* Р.Мостафин. *Картлар «хикмәте хода» диюдән артыкны белми, яшьләр сахарин-мазар ташлаганнардыр дип шикләнә иде.* А.Тимергалин

**САХАРИНЛА́У** *ф.* Сахарин катнаштыру. *Сахаринлау процессы*

**САХАРИНЛЫ** *с.* Составында сахарин булган, сахарин катнаштырылган. *Сахаринлы су. Сахаринлы сироп*

**САХАРО́ЗА** *и. нем. хим.* Үсемлекләрдәге фруктозадан һәм глюкозадан барлыкка килә торган иң киң таралган шикәр төре; төссез каты кристаллик матдәдән гыйбарәт органик кушылма. *Өлгергән җимешләрдә крахмал, шулай ук глюкоза, фруктоза, сахароза һәм бигрәк тә каротиннар күп.* Ботаника. *Нектардагы шикәр дисахариды гадәттә (40–50% очракта) сахароза хәлендә була.* Татар балы

**САХИП** *и. гар.* Ия, хуҗа. *Үткән вакытларга, тарихка әйләнеп карарга, бу кабер сахибенең бер заманда якты дөньяда йөргән заманнарын уйларга мәҗбүрият хис ителә...* М.Гафури. *Бу җирдә растлык иясе, хакыйкать сахибе сезнең явызлыкларыңызны эченә алмыш дәфтәреңезне үз кулы илә әшкярә итәр: күрсәтер.* Г.Тукай. *Мәҗмуганың җаваплы сахибе (хуҗасы) әүвәл Рифат Мөхтәсип, ә бераздан доктор Мәхмүт Аликәй була.* Х.Миңнегулов

**САХИХ** *с. гар.* 1) *иск.* Чын, дөрес, хакыйкый, шиксез. *Сахих мәгълүмат*

2) *дини* Ышанычлы, уйдырма яки хаталы түгеллеге тикшерелгән (хәдис тур.). *Ләкин Рәсүлулла һәм зур сахабәләрнең музыка тыңлаулары сахих хәдисләрдә сабит, «мизмар әшшайтан», «ләһү» диеп аталганнары хәлдә аны тыңлаганнар.* Г.Сәйфуллина

**САХРА** *и. гар.* 1) Чүл, ком даласы. *Сахра артыннан кызарып кояш күренде, дала иртәнге алсу-кызыл нурга чумды.* Г.Ибраһимов. *Муса пәйгамбәр һәм аның тирәсендәге кешеләр, Мисырдан чыгып сахра кичкәндә, ач һәм сусыз калалар.* Г.Камал. *Һәммәсе коры вә сусыз сахра вә чүлдер.* М.Гайнетдин

2) Гадәттә агачсыз киң җәйге дала, чәчәкле болын һ.б.ш.; табигать кочагы. *Яз җитү белән, сахрага, язгы дала кочагына йомраннар ауларга чыгалар иде алар.* А.Расих. *Иркен сахра уртасында киңәеп үскән ялгыз имән.* М.Маликова. *Сахра былбыллары булып Төшләремә керәсең.* Ф.Җамалетдинова

**САХТИЯН** *и. сөйл. к.* **сәхтиян**. *Сахтиян читек, сары башмак, Бассана җирне уйганчы.* Җыр. *Атып алдым ак куян, сатып алдым сахтиян; кыз дип алдым – хатын булды: зыян өстенә зыян.* Җыр

**САЧ** *и. иск.* Чәч. *Сачың аклыгы Аллаһы Тәгаләдән курку өчен түгелдер, бәлки, картлыгың өчендер.* К.Насыйри. *Шул тарак берлән утыра тузгыган сачын тарап.* Г.Тукай. *Бер уч сачы йолкынган, бөтен куллары әллә ни эшләп киселеп бәткән.* Г.Исхакый

**САЧОК** *и. рус* Балык һәм бөҗәкләр тоту өчен, конуссыман итеп эшләнгән озын саплы ятьмә. *Балык тоту кирәк-яракларын, спиннинг, сачок, ишкәк, якорь кебекләрне көймәгә ташып куйдым.* М.Әмир

**САЮ** *ф. иск.* Санау, хисаплау. *Һөнәрлесең, диде төлке, һөнәрле, Аз эш саймам ул эшне мин дә, кордаш.* Дәрдемәнд

**САЯК** *и. диал.* Эшсез; сукбай; биләмче

**САЯК-САНДЫРАК** *җый. и.* Ыбырчыбыр, әтрәк-әләм; вак-төяк (кеше тур.). *Нишләп мин урамнан кергән саяк-сандыракны сыйлыйм?* М.Мәһдиев. *Бәлки, ул мондагы саяк-сандырак арасында үз асылын тапкандыр.* Р.Зәйдулла. *Кулыннан эш килә икән, юкса элек бер саяк-сандырак иде: берничә көндә йортның эчен чистартып, юып чыгарды, тәрәзәләрен алмаштырды, ишегалдындагы үләнне чапты...* Ватаным Татарстан

**САЯРУ** *ф. диал.* Саегу. *Һәр көн бай баласының кесәсеннән ничә йөз сумнар чыгып торгач, тагын кесәсе саяра башлады.* Ш.Мөхәммәдев

**СӘБӘП** *и. гар.* **1.** 1) Берәр күренешне китереп чыгара торган шарт. *Мине үзенә бәйләүче беренче сәбәп – тынлык, табигыйлек.* И.Салахов. *Ни булды икән, нигә алай итте икән дип, сәбәбен белергә бик теләсә дә, белә алмады [Равил].* В.Нуруллин

2) Берәр хәлне аклый торган нигез, сылтау. *Ничек сәбәп табыйм моның янына керергә дим, әйтергә кирәк.* С.Рафиков. *Сәфәргә бөтенләй урынсызга бәйләнер өчен сәбәп табылды.* Н.Сәфәрев. *Күрәбез, дин белән фәнне бер-берсенә антагонистик рәвештә каршы куярлык объектив чыганак яки сәбәпләр юк.* Р.Сафин

3) Берәр эш-хәлнең килеп чыгуына этәргеч булган нәрсә яки кеше. *Шулай булса да авыз әдәбияты иҗатында мәкаль хәтле төрле бәхәскә сәбәп булган башка жанр табасы авыр булыр.* Н.Исәнбәт. *Бу вакытта аның --- үпкә чире белән интегә башлавы да моңа сәбәп булган.* Ф.Галимуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) *лингв.* Иярчен җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең сәбәбен (*1 мәгъ.*) белдерә торган. *Иярчен сәбәп җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең сәбәбен белдерә.* М.Зәкиев

2) *лингв.* Эш һәм хәрәкәтнең сәбәбен (*1 мәгъ.*) белдергән һәм фигыльгә буйсынып килгән (иярчен кисәк). *Ул иярчен сәбәп җөмлә я турыдан-туры баш җөмләнең сәбәп хәле функциясендә килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.* М.Зәкиев

◊ **Сәбәбенә керешү** Берәр нәрсәгә ирешүнең чарасын күрә башлау, шуны кайгыртырга тотыну. *Үзең яучы җибәрәм, әтиләреңнән соратам дип вәгъдә кылдың, ә үзең һаман да сәбәпләренә керешмисең.* Г.Камал

**СӘБӘПЛЕ** *с.* **1.** Сәбәп белән эшләнгән; сәбәбе, нигезе булган

**2.** *бәйл. функ.* Аркасында; сәбәптән. *Ул шул илләрдә яшәп тә кала ала иде, зур гыйлемле, күркәм холкы сәбәпле, аңа һәркайда ишек ачык булды.* Ф.Бәйрәмова. *Аны монда, болай очратырмын дип башыма да китермәвем сәбәпле, озак телсез тордым.* Ф.Яхин. *Катод белән анод арасындагы электр кыры тәэсир итү сәбәпле, көпшәдәге ирекле электроннар тизләнешле хәрәкәт итәләр.* Физика

**СӘБӘПЛЕЛЕК** *и. филос.* Берсе икенчесенең зарури барлыкка килүенә сәбәп булган объектив күренешләрнең үзара бәйләнеш һәм бәйлелек формасы. *Дөньяның үзгәреш процессында сәбәплелек хәрәкәт итә.* Философия

**СӘБӘПСЕЗ** *с.* **1.** Сәбәбе булмаган, нигезсез

**2.** *рәв. мәгъ.* Сәбәп булмый торып. *Сәбәпсез таудан таш та тәгәрәп төшми.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Алар һич сәбәпсез көләләр, шаяралар.* Ж.Рәхимов

**СӘБӘПСЕЗГӘ** *рәв.* Бернинди сәбәпсез, сәбәп булмаган хәлдә. *Бер сәбәпсезгә минем белән эшли торган ике егетне атып үтерделәр беркөн.* Р.Мөхәммәдиев. *Соңгы көннәрдә һич сәбәпсезгә уң күзе кычытып йөдәтте.* Я.Зәнкиев

**СӘБӘПТӘН** *бәйл.* Аркасында; сәбәпле. *Шул сәбәптән ул ел Мәккәгә күп хатыннар килде.* К.Насыйри. *[Күз] җил-яңгырданмы яисә башка берәр сәбәптәнме кызарган иде.* А.Шамов

**СӘБӘПЧЕ** *и.* 1) Берәр хәлнең килеп чыгуы өчен җаваплы кеше, шуның аркасында нидер булган зат. *Чөнки нәкъ менә Мөхәммәд галәйһиссәләм, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, шул авыр вакытларда кешелек тормышының алга таба дәвам итеп китә алуына сәбәпче була.* Мөселман гаиләсе календаре

2) *сөйл. к.* **сәбәп** (*3 мәгъ.*). *Әҗәленә дә шул риясызлыгы сәбәпче булган.* Э.Шәрифуллина. *Ут-күз чыгуга күбесенчә көл астында посып калган күмер яисә сиздерми генә пыскып яткан кисәү сәбәпче була.* М.Насыйбуллин. *Әйтерсең лә аларның бу очрашуларына шушы чәчәкләр генә сәбәпче булган.* К.Тимбикова

**СӘБӘТ** *и. фар.* 1) *диал.* Каркасы чыбыктан үреп ясалган, тукыма яисә тире тарттырылган капкачлы кәрзин; ябык читлек

2) *иск.* Он һәм ашлык саклар өчен кулланыла торган күп сыйдырышлы зур лар

3) Ипи саклау тәлинкәсе, икмәк табагы

**СӘБЗӘ** *и. фар. диал.* 1) Яшелчә; ашар өчен кулланыла торган яшь үлән сабаклары, яфраклары һ.б.ш.

2) Йөземнең саргылт яшел төстәге төре

**СӘВӘЛӘЙ** *и. этн.* 1) Махсус киемнәргә киенгән кеше (Яңа ел уеннары вакытында)

2) Клоун, шамакай, мәзәкче, көлдерүче кеше

3) Яңа ел уеннары вакытында киелә торган озын җиңле һәм озын чабулы кием

**СӘВӘТ** *и. гар. иск.* Укый-яза белү, грамоталы булу. *Кемнең сәвәте бар, шуның сәләте бар.* Мәкаль

**СӘВӘТЛЕ** *с. иск.* Укый-яза белгән, грамоталы. *Сәвәтле кеше гадәтле (әдәпле).* Мәкаль

**СӘВӘТЛЕЛЕК** *и.* Грамоталылык. *Укый-яза белү, сәвәтлелек арту белән язу материалына ихтыяҗ зурайгач, тузга язуга күчкәннәр.* Ф.Сафиуллина

**СӘВЕР** *и. гар.* 1) *иск.* Апрель ае. *Чөнки сәвердә болыннар чирәмгә төренеп, лаләләр чәчәк ата. Шуңа күрә мин дә: – Их, тизрәк яз килеп, сәвер яңгыры яусын иде!.. – дип ычкындырдым.* Н.Сәфәрев. *Әле сәвер аенда да күлләрдә боз була, кистереп ява.* Т.Нәбиуллин

2) *астр.* Ориониан төньяк-көнбатышта, Җәүза һәм Хәмәл йолдызлыклары арасында урнашкан зодиак йолдызлыгы; Үгезбозау. *Яна, балкый Сәвер йолдызлыгы, дөнья буйлап оча күбәләк!* Р.Әхмәтҗанов

**СӘГАДӘТ** *и. гар. кит.* Бәхет, рәхәтлек, уңыш. *Ул кызының бәхете өчен никадәр корбаннар кылып, никадәр акчалар бетереп, көчләр сарыф кылып, кызым сәгадәткә ирешә дигәндә генә, эшнең болай булуына разый була алмады ---.* Г.Исхакый. *– Һомай кошы бу, – диде бераздан әткәй. – Күптән безнең якларда күренгәне юк иде. Сәгадәт билгесе, бәхет китерә ул.* Ф.Яхин

**СӘГАДӘТЛЕ** *с. иск. кит.* Бәхетле. *[Һаҗәр] Аны-моны белештермичә генә Гариф турында уйлый, аның белән үткәргән сәгадәтле минутларын һаман саен искә төшерә.* К.Тимбикова. *Шулай итеп сәгадәтле сәгать үтә. Ул да, торып, үз урынына чыгып китә.* Р.Зәйдулла

**СӘГАТЬ** *и. гар.* 1) Тәүлекнең егерме дүрттән беренә – алтмыш минутка тигез вакыт үлчәү берәмлеге. *Бер-ике сәгать эчендә капчыкларыбызны тутырып, әйләнеп тә кайттык.* М.Әмир. *Гомерләре нибарысы ике-өч сәгать чамасы гына.* Я.Зәнкиев. *Ярты сәгать тә узмагандыр, без тау итәгенә барып җиттек.* Н.Сәфәрев

2) Тәүлек эчендәге вакытны үлчәү әсбабы. *Стенадагы зур сәгать, өй эчен яңгыратып, унны сукты.* А.Расих. *Ул сәгатенә карап алды.* З.Хәким. *Аяклы зур сәгатьнең ялтыратылган җиз теле һәм авыр герләрендә ут нурлары чагыла.* Ә.Гаффар

3) Көн уртасыннан яки төн уртасыннан исәпләп кителә торган, алтмыш минутлык вакыт үлчәме. *Каланча төнге сәгать уникене сукты.* И.Туктар. *Ләкин ул әле өйдә юк иде. Күршеләренә, кичке сәгать унберләрдә генә кайтам, дигән.* З.Фәхретдинов

4) Лекция, дәрес һ.б. берәр эшкә билгеләнгән вакыт арасы. *Миңнурый куе эңгер-меңгерне ертып юлга чыгып китте, туп-туры НКВДга кагылды: эш сәгатен иртә бетереп, начальниклар кайтып киткән булып чыкты.* Я.Зәнкиев. *Бүген дә көндезге аштан соң, авыруларның йокы сәгате үткәч, карт врач Гыймазовка Әгълам Саттаров янына керергә рөхсәт бирде.* С.Рафиков

5) Кайбер һөнәрләрдә эш өчен түләгәндә, белгечнең профессиональ сыйфатларын билгеләгәндә һ.б.ш.ларда исәпкә алына торган вакыт берәмлеге. *[Аны] Сәгатьләрен кисеп, мәктәптән китәргә мәҗбүр итәргә тырышалар икән.* А.Хәсәнов

6) Аергыч сүздән соң килеп, «вакыт, чак, момент, срок» дигән мәгънәне белдерә. *«Уразаевның актык сәгате җитте!» дип уйлады куян йөрәкле мөгаллим һәм, куркыныч урыннан ераграк*

*китәр өчен, томырылып чаба башлады.* Я.Зәнкиев. *Менә ул --- тәҗрибәле өлкән апаларча иттереп әйтә салды: – Инде бәхетле сәгатьләрдә кайтып төшүләрең булсын!* Ә.Касыймов

◊ **Сәгате белән** Бик тиз. *Гайбәт сәгате белән шәһәрне каплый.* Г.Ибраһимов. **Сәгате-минуты белән** Шунда ук, тиз арада. *Хәбәр, әлбәттә, сәгате-минуты белән авылга таралып өлгерде.* Я.Зәнкиев. *Сәгате-минуты белән ишәя барган шәрә болачылар алае борынгы кыргый кешеләрнең торлагын хәтерләтә иде.* Ж.Рәхимов. *Ике биек тау сыртының уртасына утырган һәм инде галәмәт зурайган бу заводның төтенен Агыйдел буйлап искән җил бүген дә сәгате-минуты белән читкә алып китә.* В.Имамов. **Сәгать сугу** 1) Берәр вакыйганың, хәлнең булуына, берәр эшне эшләргә тарихи һ.б. шартлар өлгерү. *Ияк кагып кына исәнләштеләр, күзләр тышка – сәгате сукса да, һаман яктыра алмаган көнгә текәлде.* Я.Зәнкиев; 2) Яшәү чоры бетү, үлү, һәлак булу, вакыты җитү. *[Ризван Рухы:] Җир йөзендә соңгы сәгатең сукканчы, без сине сакларбыз.* Ә.Гаязов. *[Нурали:] Хәнҗәрдән котылдың, сынган канат урынына башка терәк таптың! Тик барыбер минем үчтән котыла алмадың. Сәгатең сукты! Төш тәхеттән! Төш!* М.Маликова. **Сәгать эчендә** *к.* **сәгате белән**. *Таратып җибәргәч, көтү сәгать эчендә әллә ничә дисәтинә җирне иңләп ала.* М.Гали

**СӘГАТЬЛӘП** *рәв.* 1) Бер яки берничә сәгать чамасы. *Район үзәгеннән килеп җиткәнче, тагын берәр сәгатьләп вакыт узар әле.* Ж.Дәрзаман. *Ләкин бер сәгатьләп вакыт узгач, ашаучылардан бушап калган савыт-сабаларны юып торган чакта, тиктомалдан гына үзалдына үзе директорга биргән җавабын кабатлап куйды.* М.Әмир

2) Нормаланган вакыт белән, сәгатьләр белән билгеләп. *Бездә сәгатьләп эшләү каралган, акчасы да чыдарлык, сөйләшеп карыйм әле.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Тиешле яки фаразланган вакытыннан күпкә тизрәк, бик тиз. *Сугыш кешеләрне еллап түгел, сәгатьләп, минутлап картайтты.* Н.Дәүли. *Мөхәммәт Уразаевның абруе көнләп түгел, сәгатьләп үсә торды.* Я.Зәнкиев

**СӘГАТЬЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Озак, берничә сәгать буена. *Бер эш яки бер сүзне аңламый, аз гына ялгыш селкенү яки берәр офицерга честь бирергә өлгерә алмый калу кебек эшләр өчен сәгатьләрчә мылтык күтәреп тору кебек җәзалар [булды].* М.Гафури. *[Күзге алдында] сәгатьләрчә ләззәтләнә иде [кыз].* Г.Ибраһимов

**СӘГАТЬЛЕ** *с.* 1) Нормасы, вакыт дәвамы билгеләнгән; сәгатьләр белән исәпләнә торган. *Монда сиңа завод түгел, сәгатьле эш түгел.* Н.Фәттах. *Безнең сәгатьле эш түгел бит, иҗат белән янасың. Көндез – репетиция, кич – сәхнә.* Т.Нәҗмиев

2) Сәгате булган. *Берәүгә дә сүз кушмыйча гына кепкасын салып, сәгатьле стена буенда торган өстәл өстенә ташлады да, кесәсеннән эре-эре шакмаклы яулык чыгарып, маңгай тирләрен сөртте.* М.Әмир. *Приборның иңен, буен күрсәтә, уртасына сәгатьле манара куеп, иң өскә канатларын җәйгән каракош утыртырга куша.* И.Нуруллин

**СӘГАТЬЛЕК** *с.* Ничәдер сәгать дәвам иткән, билгеле сәгатькә исәпләнгән. *Беренче мәсьәлә ун сәгатьлек эш көне хакында иде.* А.Алиш. *Аны яңарту өчен, --- уналты сәгатьлек эш көне исраф итәргә кирәк.* М.Юныс

**СӘГАТЬЧЕ** *и.* Сәгать ясау яки төзәтү эшендә эшләүче, шул эшнең остасы. *Монда танылган сәгатьчеләр, танылган гармунчылар, драп, бостон, габардин белгечләре, велосипед, фотоаппарат осталары бар.* М.Мәһдиев

**СӘГАТЬЧЕЛЕК** *и.* 1) Сәгатьче эше, һөнәре, кәсебе. *[Мәскәү сәгатьчеләре] Чистайның егетләрен һәм кызларын нечкә һөнәргә – сәгатьчелек эшенә өйрәтә башладылар.* М.Максуд

2) Сәгать ясау сәнгате һәм сәнәгате

**СӘДӘП** *и. сөйл. к.* **сәдәф** (*2, 3 мәгъ.*). *Ильяс тәкъдиме белән хуҗа апа авыл советына хәзер үк барырга тиеш булды: председательне куып җитү нияте белән, ашыгыч киенеп, сәдәпләрен каптыра-каптыра, алар артыннан китте.* Ә.Баян. *Үзенең гаҗәпләнүенә каршы, Гафур Хөсәен янында Газизне һәм киң җилкәле, каракучкыл йөзле, бөркет сурәтләре ябыштырылган сәдәпләре ялтырап торган студент тужуркасы кигән яшүсмерне очратты.* Г.Шәрипова

**2.** *с. мәгъ.* Сәдәфтән (*1 мәгъ.*) ясалган, шуны катнаштырып эшләнгән. *Тоныкфотографиядәге хатын-кызлар төркеме дә һәм, алар белән янәшә, сәдәп кабырчыклар белән бизәлгән рам эчендәге Хәсән портреты да җанлы кебек күренәләр.* К.Нәҗми

**СӘДӘФ** *и. гар.* **1.** 1) Бизәнү әйберләре, төймәләр һ.б.ш. ясауга китә торган материал, перламутр (гадәттә, бака кабыгының матур төс биреп тора торган эчке катламы)

2) Киемнең ике чабуын, изүнең ике ягын, җиң беләзеген һ.б. эләктереп тоту өчен хезмәт итә торган, гадәттә яссы түгәрәктән гыйбарәт эләктергеч; төймә. *Аның башында кокардалы фуражка, өстендә ялтыравыклы сәдәфләр тагылган хәрби кием.* М.Латыйфуллин. *Яшел өчпочмакны хәтерләткән шалаш эченнән, чалбар сәдәфләрен төймәлитөймәли, Гайнулла абый чыгып килә иде.* Р.Низамиев

3) Таблетка, түгәрәк формасындагы берәр нәрсә. *Әйтик, төш алдыннан тамак ялгап алырга дигән ризыклары боларның бармак очы кадәрле ике-өч сәдәфтән гыйбарәт.* А.Хәсәнов. *Оркыя ханым бер сәдәф баш даруы капты һәм болай да ялтырап торган бүлмә идәннәрен җыештырырга, юеш чүпрәк белән шкаф-өстәлләрне сөрткәләргә кереште.* Ф.Латыйпов

**2.** Сәдәфтән (*1 мәгъ.*) ясалган, шуны катнаштырып эшләнгән

**СӘДӘ́ФГӨЛ** *и. бот.* Гөлбадран, күпьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **пижма**

**СӘДӘФЛӘ́Ү** *ф.* Сәдәфкә эләктереп кую, төймәләү. *Изүне сәдәфләү*

**Сәдәфләп кую** Сәдәфләгән хәлгә китерү

**Сәдәфләп тору** Сәдәф белән мәшгуль булу

**СӘДӘФЛЕ** *с.* Сәдәф ярдәмендә эләктерелә торган, сәдәфе булган. --- *киенүгә артык игътибар бирмәгән*

*егетләрнең өстендә ак перламутр сәдәфле, погонлы, чем кара төстәге күлмәк, балагы тарайтылган яшел чалбар, аякларында калын табанлы туфли иде.* Ф.Латыйпов. *Бичара мәгъшук гарәп җитезлеге белән килеп тә җитә, зәңгәр сәдәфле башлыгымны кулларыма да тоттыра.* Р.Рахман

**СӘДӘ́Ф ҮЛӘН** *и. бот.* 1) Мальвачалар семьялыгыннан ал яки ак чәчәкле берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **просвирняк**

2) Мальвачалар семьялыгыннан Европа, Азия илләрендә үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **алтей**

**СӘДӘФЧЕ** *и.* Сәдәп ясаучы яки шуның белән сату итүче

**СӘЕД** *и. гар.* 1) *иск. дини к.* **сәет**. *Әйтик, халык телендә Бөек Болгар иле, аның башкалалары, ил башында торган ханнары, ханбикәләре, әмирләре, сәедләре --- турында татар халык иҗатында әле хәзер дә бихисап риваятьлегендалар йөри.* Татар халык иҗаты

2) Әфәнде. *Сәед бине Әнәс: «Сез сәед, мин Әнәс улы», – диде.* К.Насыйри

3) *тар.* Казан ханлыгында төп дин башлыгы. *Илдә ханнан соң икенче урында торган кеше ислам дине башлыгы – сәед булган.* Ф.Бәйрәмова

**СӘЕР** *с. гар.* Гадәти булмаган, нәрсәсе беләндер ишләреннән аерылып тора һәм бераз гаҗәпләндерә торган. *Китеп күп тә тормады, аңардан сәер хатлар килә башлады.* М.Әмир. *Куллары богауланган сәер төркемдәге кешеләрне атлы сакчылар тимер юл станциясенә озатып баралар иде.* М.Латыйфуллин

**СӘЕ́Р ИТҮ** *ф. иск.* Карап, күзәтеп тору. *Хосусан, әткәсе сугышка китү вакыйгасы аның сугыш хакындагы элекке тар гына күләмдәге аңын яхшы ук киң итеп сәер итте.* Ш.Камал

**СӘЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Сәергә әйләнү. *Шуннан соң Хәлидә отыры сәерләнде.* Н.Гыйматдинова

2) Җиңелчә гаҗәпсенү, әсәрләнү. *Зөһрә ханым сәерләнеп иңбашларын җыерып куйды: – Аңламыйм мин сезне...* Ә.Еники

**Сәерләнә бару** Торган саен, көннән-көн ныграк сәерләнү

**Сәерләнә төшү** Бераз сәерләнү

**Сәерләнеп алу** Кыска вакыт эчендә сәерләнгән хәл кичерү

**Сәерләнеп йөрү** Гел сәерләнү; озак вакыт сәерләнү. *Зәңгәр күзле ат күреп сәерләнеп йөрде ул соңгы көннәрдә.* З.Хөснетдинов

**Сәерләнеп калу** Билгеле бер хәлдән, вакыйгадан соң сәерләнгән хәлгә килү

**Сәерләнеп китү** Соңгы арада кинәт сәерләнү. *Ишектән мин күренгәч тә, ул сәерләнеп китте.* Х.Кәрим

**Сәерләнеп кую** Кинәттән генә сәерләнү

**Сәерләнеп тору** Әле, хәзер сәерләнү. *[Сәрбиҗамал:] Бу нишләп килми икән инде? --- Бик йөрәкләрем дә сәерләнеп тора. Әллә берәр эш буламы, югыйсә бу кадәр күңелемә һичбер вакытта курку төшкәне юк иде.* Г.Камал

**СӘЕРЛЕК** *и.* 1) Сәер булу. *Шунысын әйтә алам: әдәби китаплар укый башлагач, Галимҗан Ибраһимов телен мин, бернинди сәерлек күрмичә, нәкъ безнең үз өебез теле кебек кабул иттем.* М.Әмир. *Сәер чорның сәерлеге – Үзе зур тамаша.* Б.Ибраһим

2) Сәер кыланыш, сәер эш. *Тик нишлисең, кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың дигәндәй, яратырга туры килә аларны, шул килеш, бөтен сәерлекләре белән яратырга туры килә.* Э.Шәрифуллина. *Дөрес, әкият ярату әллә ни сәерлек түгел түгелен.* Ж.Дәрзаман

**СӘЕРСЕНҮ** *ф.* Бераз гаҗәпсенү, әсәрләнү. *Дөресен әйткәндә, бу укымышлы кыяфәтле, эре сөякле кеше Яковны шактый сәерсенеп, хәтта күңелсезләнә төшеп каршылады.* А.Расих. *Сәйдә җиңги бу сорауны аңлап җитмәү сәбәпле, райком секретарена бераз сәерсенеп карады.* С.Рафиков

**Сәерсенә төшү** Беркадәр сәерсенү

**Сәерсенеп калу** Берәр гамәлдән, эштән соң сәерсенү. *Төпчек уллары Рәмзи өйләрендәге галәмәт хәлгә --- утә гаҗәпсенеп һәм сәерсенеп калган иде.* Э.Касыймов. *Әмма тегеләре кинәт сәерсенеп калдылар: серле Коръән сүрәсенең бик тә гади сүзләрдән торуы шикләндергән иде аларны.* Ж.Рәхимов

**Сәерсенеп кую** Бераз сәерсенү. *Ул тагын юлга чыкты, мотоциклның ерак та китми кире борылуын күреп, бер мәлгә сәерсенеп куйды.* М.Маликова

**Сәерсенеп тору** Сәерсенгән хәлдә булу. *Ә без, малайлар, бу хәлгә бераз сәерсенеп тордык та, берни булмагандай, яңадан уенybызны дәвам иттек.* В.Нуруллин

**Сәерсенеп утыру** Әле, хәзерге вакытта сәерсенгән хәлдә булу

**СӘЕРЧЕ** *и. иск. кит.* Сәер итүче, күзәтеп, карап торучы; тамашачы. *Тирә-ягыбызны сәерчеләрнең көймәләре уратып алганнар, ишкәк тавышы да, өн дә чыгармыйча, Мәгъзүмәнең тавышын тыңлыйлар.* Ш.Әхмәдиев

**СӘЕТ** *и. гар. дини* Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кеше. *Ләкин алар күп түгел, иң кодрәтле морзалар, әмирләр, иң мөһиме – сәет белән карачы үзе кырымнарны яратмый.* Р.Зәйдулла

**СӘЖДӘ** *и. гар.* 1) Йөз белән җиргә капланып иелү хәрәкәте. *Инде бар җан дөньям егылды Сиңа Моңсу бер бакча Сәҗдәгә – Кояш, Ай, Җир дә...* Р.Гаташ

2) *дини* Гадәттә намазда маңгайны, учларны, тезләрне һәм аяк бармакларын җиргә тидереп тору хәле. *Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан? Тәзкирәңә мөслим диеп игълан таккан? Кемнәр сине, намаз диеп, сәҗдә диеп, Юкка тузанлы мәсҗедләрдә аунаткан?* Г.Тукай. --- *Бервакыт сәҗдәгә китүебез булды, мулланың: «Нишлисең, Хуҗа?!» – дип кычкырып җибәрүе булды. Аны бу ахмак арттан чабуыннан тарткан икән.* Н.Исәнбәт

**СӘЖДӘ́ ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **сәҗдә кылу**

2) Гыйбадәт кылу, дин тоту. *Халык корбан чалсын, сәҗдә итсен, күпләп сәдака бирсен!* Р.Батулла. *Сират күпере төбендә Рәсүлулла талмый елый, Башын сәҗдәдән алмыйча, гасый өммәтләрен сөйли.* Мөнәҗәт

**СӘЖДӘ́ КЫЛУ** *ф.* 1) Йөз белән җиргә каплану

2) *дини* Намазда тезләнеп һәм учларга таянып, маңгай белән җиргә тию. *Гали бакты, күрде бер тимер капуг, Сәҗдә кылды, Тәңрегә кылды тапут.* Кисекбаш китабы. *Бушка китте күп минем Елап кылган сәҗдәләр.* Һ.Такташ. *Нинди уйга чумдың әле, Әй, газиз*

*кәгъбәм минем. Менә тагын яныңа мин Сәҗдә кылырга килдем.* Г.Морат

3) Кемне яки нәрсәне дә булса чиксез олылау, табынырлык дәрәҗәгә кую. *Табындым, сәҗдә кыйлдым мин сөйгән җанашның алдында, Өмид иттем вә курктым да, кызардым һәм оялдым да.* Г.Тукай. *Матурлык алдында сәҗдә итү – көферлек! Соң, илаһым, алай булгач, безгә ник мондый җан бирдең? Ник безне туң йөрәк, тупас күңел итеп яратмадың?* Г.Ибраһимов

**СӘЙЛӘН** *и. гар.* **1.** Муенсага, калфакка тезеп чигү һ.б.ш. бизәнү әйберләре ясау өчен кулланыла торган, уртасы тишекле вак пыяла төймәчек. *Укалап һәм сәйлән ташы тезеп чигелгән түбәтәен киеп кергән Ак бабай күз тидерерлек дәрәҗәдә ягымлы, мөлаем, якты иде.* Г.Гыйльманов. *Еш кына җеп белән беррәттән энҗе, сәйлән кулланыла.* Татар чигүе

**2**. *с. мәгъ.* Шушы материалдан ясалган. *Сәйлән муенса*

**СӘЙРАН** *и. иск. гар.* **1.** Ачык һавада йөрү, һавага чыгып ял итү; гизү. *Падиша әйтә: – Әллә кайчаннан бирле кәрван үткәне юк, кәрван очрамасмы икән дип, сәйранга чыккан идек, – ди.* Әкият. *Кичләрен ул җәяүле сәйранга чыгарга ярата.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Рәхәт, күңелле, хозур; иркен. *[Казахстанның] сәйран далаларын Алыштырды шулай таш таулар. Шул тауларда, ахры, уяндылар Иҗат серен аңлый башлаулар!* Н.Арслан

**СӘЙРА́Н ИТҮ** *ф. кит.* Саф һавада йөрү, сәйранда булу. *Гомер – дала, Син – бер бала, сәйран ит.* Р.Гаташ

**СӘЙРА́Н КЫЛУ** *ф. к.* **сәйран итү**. *Өченчедән, планетаны сәйран кылып йөргәндә, мин гаҗәеп агачларга тап булдым.* А.Тимергалин. *Әниебез исән-сау иде әле, айга якын бергә-бергә, аралашып, рәхәтләнеп сәйран кылып йөрделәр.* К.Миңлебаев

**СӘЙРАНЛЫК** *и.* 1) Күңеллелек, рәхәтлек, хозурлык; һавада күңел ачу. *Салкынча сәйранлык, яшеллек, муллык эчендә Шаһмара талгын бер ләззәт кичерә иде.* Р.Батулла

2) Сәйран итә, күңел ача торган урын. *Бер адәм үзенең сәйранлыкта гизгәнене күрсә – мәшьүм [шомлы] төштер: сәфәр чыгар вә күп мәшәкатьләргә грифтар булыр. Садака бирмәк тиештер.* Ф.Әмирхан

**СӘЙЯР** *и. гар. иск.* Гизүче, сәяхәтче, юл йөрүче. *[Фирдәүсинең] «Шаһнамә»сен кабул итми шаһлар, Пайтәхетләр, илләр гизсә дә, Кире кайта арып-алҗып сәйяр. Төшермиләр озак искә дә.* Н.Арслан

**СӘЙЯХ** *и. гар. иск.* Сәяхәтче, турист, дөнья гизүче, илгизәр. *Ачыккан сәйях, тиз генә төшеп, ярманы чүпләргә башлады.* Г.Тукай. *Дөрес, Мэн-Хун дигән бер кытай сәйяхы шундый бер хәбәр яза.* Р.Вәлиев

**СӘКӘЛ** *и.* Атның бәкәлендәге чук; ат бәкәленең ак булып аерылып торган урыны. *Атны сәкәленә карап таныйлар*

**СӘКЕ** *и.* 1) Элекке авыл өендә идәннән ярты метр чамасы биеклектә калын такталардан җәеп эшләнгән, гадәттә бөтен түрне алып торган утыру-яту урыны. *Сәкесе булмаганга, тәрәзәсе бик биек иде; үзе бер генә кат булганга, бертуктамаенча суык агып тора иде.* Г.Исхакый. *Ике якта киң сәкеләр, уртадагы гади керосин мичкәсеннән ясалган мичтә каен утыны дөрләп яна.* Г.Әпсәләмов

2) Шул җиһазга охшатып эшләнгән төрле утыру-яту урыны; нар. *Вагон сәкесе. Казарма сәкесе*

3) *диал.* Үлчәү берәмлеге: өстәлгә җәеп киптерелгән җиләк-җимеш кагы күләме. *Ике сәке алма кагы әзерләү*

4) *диал. иск.* Киндер сугу станы

**СӘКЕЛЕ** *с.* Сәкесе булган, сәке белән җиһазланган. *Алты атналык малай шулай итеп волость үзәгендәге салкын квартирдан Фәхрисламның сәкеле җылы өенә күчте.* М.Мәһдиев. *Бу як сәкеле булуы белән аерылып тора, урын-җир, мендәр-түшәккә, намазлыкларга бай.* Ә.Гаффар

**СӘКЕЛЕК** *с.* Сәке өчен яраклы, җитәрлек; сәкегә дип билгеләнгән. *Мунчаны тиз генә бетереп алырга кирәк. --- Идәнгә үзебезнең такталар да ярар; ләүкәлек, сәкелек яңа такта алырбыз.* М.Фәйзи

**СӘКЕН** *и. гар.* **1.** 1) *лингв.* Гарәп язуында хәреф өстенә куелган һәм киләсе сузык авазның булмавын белдерә торган хәрәкә. *Сәкен кечкенә түгәрәкне хәтерләтә*

2) *күч. жарг.* Эндәшмәү, сөйләшмәү; тынлык

**2.** *ы. мәгъ. иск.* «Эндәшмә, дәшмә, шым бул, әйтәсе булма» дигән мәгънәдә

**СӘКЕНЛЕ** *с. лингв.* Өстендә сәкене булган (хәреф тур.). *Ир токым булган сүзләрне шуннан беләбез ки, ул сүзләр каты һәм йомшак сәкен белән, сәкенле «й»гә бетәләр.* Г.Тукай. *Сәкенле нун һәм тәнвин кагыйдәләре*

**СӘЛАМ** *и. гар.* Күрешкәндә яки хат язганда, дуслык, яхшы теләк һ.б.ш. хисләрне белдерә торган нәзакәт сүзе. *Татарчалап биргән сәламемә генә ни сәбәпледер җавап бирми һаман.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулай бәргәләнеп йөргәндә, аның янына Мөхәммәт Уразаев килеп керде. Сәлам алыштылар.* Я.Зәнкиев. *Иптәшләрегезгә рус туганнарының кайнар сәламен тапшырыгыз...* Ә.Давыдов

◊ **Сәлам әйтү** Исәнләшү сүзләрен җиткерү, тапшыру. **Сәлам бирү** *к.* **сәламләү**. *Харис, башындагы киез эшләпәсен салып, һөнәрчеләргә сәлам бирде.* М.Латыйфуллин. *Кычкырып сәлам бирәләр, зурлап күрешәләр.* Х.Ибраһим. *Барысы да сандугачка сәлам бирганнәр.* Р.Хафизова. **Сәлам кайтару** *к.* **сәламне алу**. **Сәламне алу** Сәламгә, исәнләшү сүзенә җавап кайтару. *Шәмгун карт, гадәтенчә, ишекне киң итеп ачкач, әдәп өчен рөхсәт сорап, сәлам биреп керде. Өстәл янындагылар, аның тавышын ишетеп, күтәрелеп карадылар, сәламен алдылар.* А.Шамов. **Сәлам хаты** Исәнлек-саулык турында гына, кыскача гына язылган хат. – *Тәмле үлән чәе белән сыйлап җибәрсәк, икенче килгәндә безгә бирәр өчпочмаклы сәлам хаты калдырып китмәсме? – дип, әбием мине почта ташучы апайны каршы алырга йөгертте.* А.Хәсәнов

**СӘЛАМӘТ** *с. гар.* 1) Таза-сау, исән, чирле түгел. *Сыер исән-сау, таза, сәламәт, ел саен бер бозау алып кайтып бирә.* Я.Зәнкиев. *Ана сөтен озак имгән бала сәламәт, таза бәдәнле, озын гомерле була.* Э.Шәрифуллина

2) *күч.* Дөрес, файдалы, урынлы, тиешле дәрәҗәдә булган. *Ул – ник*

*характерлы тынгысыз җан, иҗатта сәламәт атмосфера саклаучы, тирән фикерле, таләпчән, сүзнең кадерен белүче.* Ватаным Татарстан

**СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Савыктыру, сәламәт итү. *Бу яшь галим аз заманда шөһрәте илә дөньяны тотты, һәр җирдә ул галимнең падишаһны бик каты авырып яткан җиреннән сәламәтләндергәне сөйләнә иде.* Г.Тукай. *Мине сәламәтләндер, шифа бир, аякларымны, гомумән, бөтен гәүдәмне терелтсәң иде.* Идел

2) *күч.* Тәртипкә салырга, нормаль хәлгә кертергә, яхшыртырга. *Вазгыятьне сәламәтләндерү*

**Сәламәтләндерә бару** Торган саен сәламәтләндерү

**Сәламәтләндерә башлау** Сәламәтләндерү билгеләре сизелү

**Сәламәтләндерә төшү** Беркадәр сәламәтләндерү

**Сәламәтләндереп бару** Аз-азлап сәламәтләндерү

**Сәламәтләндереп җибәрү** Кинәт сәламәтләндерү. *Иптәше ышанып әйткән сер аны ничектер ныгытып, сәламәтләндереп җибәргәндәй булды.* Г.Әпсәләмов

**Сәламәтләндереп килү** Күптәннән бирле сәламәтләндерү

**Сәламәтләндереп китү** Тиз арада сәламәтләндерү

**СӘЛАМӘТЛӘНҮ** *ф.* Савыгу, тазару. *Тазарып, сәламәтләнеп, август башы җитеп, Петербургка кайткач, Шәмсинең урынсыз калганлыгы беленде.* Г.Исхакый. – *Йокы тизрәк сәламәтләнергә ярдәм итә ул,* – *дип, врач чыгып китте.* В.Нуруллин

**Сәламәтләнә бару** Торган саен, көннән-көн сәламәтләнү

**Сәламәтләнә башлау** Сәламәтләнүгә таба йөз тоту. *Дүртенче тапкыр яраланган бу командир бик авырлык белән генә сәламәтләнә башлый.* С.Шакир

**Сәламәтләнә төшү** Беркадәр сәламәтләнү

**Сәламәтләнеп бару** Аз-азлап сәламәтләнү

**Сәламәтләнеп җитү** Тулысынча сәламәтләнү

**Сәламәтләнеп килү** Сәламәтләнүгә таба бару

**Сәламәтләнеп китү** Тиз арада сәламәтләнү

**СӘЛАМӘТЛЕК** *и.* Саулык, тазалык. *Ходай сәламәтлек кенә бирсен, күз карасыдай кадерле уллары бер заман үсеп җитәр, ил-көнгә файдалы егет булыр, иншалла!* Р.Низамиев. *Тирә-якта якын кешеләрем дә юк. Сәламәтлек тә бар белән юк арасында гына.* Ф.Галиев

**СӘЛАМӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Саулыкны югалту, сәламәтлек начарлану

**Сәламәтсезләнә бару** Торган саен сәламәтсезләнү

**Сәламәтсезләнеп китү** Тиз арада, кинәт сәламәтсезләнү

**СӘЛАМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Исәнләшү сүзләрен әйтеп яки ишарәләр белән мөрәҗәгать итү, күрешү. *Иң әүвәл ул кулын күкрәгенә кушырып – йорт иясен, аннары гына илчеләрне сәламләде.* Р.Зәйдулла. – *Хәерле кич! – дип сәламләде ул [Сөләйманов] бүлмәдә җыелган кешеләрне.* Ф.Галиев

2) Тәбрикләү, котлау. *Һәммә тәбрикләргә каршы: – Юк, сез мине сәламләмәгез, мине тәбрик итмәгез!.. Сезгә мин җырламыйм, --- Гөлбикә моңлана...– диясем килә иде.* Г.Ибраһимов

**Сәламләп калу** Сәламләргә өлгерү. *Бер сүз дә куша алмыйча, бары тик күз карашым белән генә сәламләп калдым мин аны.* Ш.Маннур

**Сәламләп тору** Хәзер сәламләү, сәламләү белән шөгыльләнү

**СӘЛӘМӘ** *с.* **1.** 1) Нык тузган, искергән, ерткаланып, тишкәләнеп беткән; алама (гадәттә, кием тур.). *Йорты сәләмә, яңасына нигез дә салмаган иде.* Н.Гыйматдинова. *Аркаларына киндер капчык аскан сәләмә киемле ирләр, балалар, хатын-кызлар, авылларын ташлап, чит җирләргә китеп баралар.* М.Латыйфуллин

2) Шундый киемле. *Йөзеннән нур качкан, начар киемле, сәләмә кешеләргә станция, пристань тирәсендә милиция-фәләннәрнең шикләнеп карауларын һәм эзәрлекләүләрен уйлап алды Исхак.* С.Рафиков

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ертык-тишек, искергән, тузган кием. --- *малайлар гына бер-ике тапкыр Башкорт янына килеп, аның сәләмәгә төренгән гәүдәсенә карап тордылар да, искитәрлек нәрсә тапмыйча, теш арасыннан эре генә черт итеп төкереп, үз юлларына китеп бардылар.* Р.Зәйдулла. *Ул, муллалар чыгып китүгә, сәкедә, сәләмәләргә төренеп, баладан соң авырып яткан Варвара түтәйнең яшьле күзләренә карый.* В.Нуруллин

2) Нык тузган, искереп беткән әйбер. *Бу арба сәләмәсен ватып ягарга кул бармый иде.* Г.Гобәй

3) Искергән, тузган әйбердән аерылып торган кисәкләрнең берсе. *Хәерче, сәләмәләре җилфердәп торган иске киемле карт булу өстенә, аксак та иде.* А.Әхмәт

4) *күч.* Ниндидер зур, күләмле нәрсәнең вак-вак аерым кисәкләре. *Күк йөзе тәмам ачылган, анда-санда болыт сәләмәләре генә күренә, һәм аларның шәүләсе чөгендер өеменә чүмәшкән егетнең йөзенә төшкән иде.* Р.Зәйдулла

**СӘЛӘМӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Нык тузып, сизрәп, ерткаланып бетү, сәләмәгә (*1 мәгъ.*) әйләнү. *Өстендәге киемнәре сәләмәләнгән, сакал-мыеклары да күптән кырылмаган.* Г.Гыйльманов

2) Сәләмәгә (*2 мәгъ.*), сәләмә киемлегә әйләнү

**Сәләмәләнә бару** Торган саен ныграк сәләмәләнү

**Сәләмәләнә башлау** Сәләмәләнүгә таба йөз тоту. *Җәй, кыш булуга карамастан, сәләмәләнә башлаган сары дуплы туннан гына йөри, иске бүреген генә басып кия.* Г.Толымбай

**Сәләмәләнә төшү** Беркадәр, бераз сәләмәләнү; тагын да ныграк сәләмәләнү. *Тоткын балалар элеккегә караганда да сәләмәләнә төшкәннәр, кыйналудан йөзләре, күз төпләре күгәргән иде.* А.Әхмәт

**Сәләмәләнеп бару** Әкренләп сәләмәләнү

**Сәләмәләнеп бетү** Тәмам, ахырына кадәр сәләмәләнү. *[Сара:] Агачтан агачка сугылып, мин хәлдән тайдым... Мине куркыныч җанварлар куды... Әнә сәләмәләнеп беткәнмен.* Ф.Бурнаш

**Сәләмәләнеп калу** Берәр вакыйгадан, эштән соң сәләмәләнгән хәлгә килү

**Сәләмәләнеп килү** Күренерлек сәләмәләнү

**СӘЛӘМӘЛЕК** *и.* Сәләмә булу. *Газаплы елларны күп күрдем: сугыш вакыты, ачлык, сәләмәлек, туганнарымның үлеме.* Шәһри Казан. *Киеменең сәләмәлегенә исең китәр*

**СӘЛӘТ** *и. гар.* 1) Кешенең тумыштан ук килә торган нәрсәне дә булса булдыру, яхшы эшләү, башкара алу осталыгы; кабилият, талантлылык. *Ходай минем бармакларга сәләт бирсә, аңа карурман кураедай моңлы тавыш биргән.* Ш.Маннур. *Укырга сәләтем булганга, абыстай мине ир балалар мәктәбенә бирергә киңәш иткән икән.* Н.Сәфәрев. *Табигать Садыйкка моңлы тавыш, музыкага сәләт бирә, җыр аның юанычы була.* С.Шакир

2) Нинди дә булса гамәл үтәү мөмкинлеге, сыйфаты, үзлеге, хәле; шулай ук нинди дә булса гамәлне үти алу. *Айсетдинне күргәч, ул бер мәлгә уйлау сәләтен дә югалтты.* Я.Зәнкиев. *Органик матдәләрдә галоген атомнары ковалент бәйләнеш белән бәйләнгәннәр, ягъни алар ионлашу сәләтенә ия түгел ---.* Органик химия

**СӘЛӘТЛЕ** *с.* 1) Берәр нәрсәгә сәләте (*1 мәгъ.*) булган, булдыклы, кабилиятле. *Шуңар күрә дә Батыр алдынгылар рәтеннән төшеп үк калмаса да, зирәк, үткен, сәләтле малай булуына карамастан, иң беренче укучы булып бара алмый иде.* М.Әмир. *Сәләтле шәкертенең һәр уңышына фрау балаларча куана, аңа карап, Азат та ихластан елмая...* А.Тимергалин

2) Нәрсә дә булса эшли ала торган; билгеле бер мөмкинлеккә ия булган. *Гомумән сабыр табигатьле, беркайчан да кутәрелеп бәрелми торган Хөсәенне мондый кискен сүзләр әйтергә сәләтледер дип һич тә уйламый иде Җәгъфәр.* А.Расих. *Кем кулына мылтык тотарга сәләтле, иртәнге алтыга шушы урынга җыелырга.* Я.Зәнкиев

**СӘЛӘТЛЕК** *и. ялг. к.* **сәләтлелек**. *Дөресен генә әйткәндә, җыргамузыкага сәләтлегем ягыннан мактаныр җирем юк.* М.Әмир. *Ул кадәр көчне кире кагу өчен бик зур сәләтлек кирәк.* Г.Бәширов

**СӘЛӘТЛЕЛЕК** *и.* Сәләтле булу; сәләт. *Коллектив җанлы булу, кешелекле мөнәсәбәтләр, хезмәткә сәләтлелек халык аңында һәрчак мактауга, олылауга лаеклы сыйфат саналган.* Ф.Хатипов. *Энтузиазм, эшкә сәләтлелек игътибарсыз калмады.* Х.Вәлиәхмәтов

**СӘЛӘТСЕЗ** *с.* 1) Сәләте (*1 мәгъ.*), осталыгы булмаган, булдыксыз, кабилиятсез. *Сәләтсез сәнәк сындыра, көчсез көрәк сындыра, диләр.* М.Насыйбуллин. *Ул Камәрияне надан, сәләтсез кешегә исәпли һәм хатын-кызларның дәрәҗәсен үстерүдә аңа бернинди дә өмет багламый иде.* М.Маликова

2) Билгеле мөмкинлеккә, үзлеккә ия булмаган. *Әйтүләренә караганда, гомумән ул семья корырга сәләтсез, гермофродит.* А.Расих. *Җылыткан вакытта сахароза салынган пробиркада бернинди үзгәреш булмый, бу – сахарозаның кайтару реакцияләренә сәләтсез икәнен күрсәтә.* Органик химия

**СӘЛӘТСЕЗЛЕК** *и.* Сәләтсез булу. *Сәет үзе өчен бер аяныч хакыйкать ачты: тирә-юнендәге кешеләр белән күбрәк аралашкан саен, үзенең көчсезлеген, сәләтсезлеген аныграк күрә баруын тойды.* М.Хәсәнов

**СӘЛӘФИ** *и. гар.* Сәләфилек тарафдары. *Алар үзләренең чын йөзен яшереп, ваһһабилар, сәләфиләр һәм башкалар битлеге артына яшеренеп, җәмгыятьнең астын өскә китерергә, исламны һәм мөселманнарны пычратырга омтыла.* Кызыл таң

**СӘЛӘФИЛЕК** *и. дини* Беренче буын мөселманнарның һәм тугры хәлифәләрнең генә яшәү рәвешен һәм динне аңлавын иң дөрес юл санаган, соңыннан кертелгән һәрнәрсәне бидгать дип таныган сөнни исламдагы юнәлеш. *Анда Татарстандагы сәләфилек хәрәкәтенә караган кешеләрнең һәм уку йортларының исемнәре дә китерелә.* Безнең гәҗит

**СӘЛБЕРӘВЕК** *с. диал.* Тузып беткән, формасын югалткан. *Аның утлы көлгә болганып көйгән пумала шикелле сәлберәвек сакал төкләре арасыннан ачы тавыш җуылдап чыкты ---.* К.Нәҗми

**СӘЛБЕРҮ** *ф. диал.* Сүсәреп бетү, тәмам таушалу. *– Анысыннан эш тормас, – диде Мостафа һәм киез кисәкләре сәлберәп торган ертык клеёнкалы ишеккә юнәлде.* К.Нәҗми

**СӘЛЕНДЕРҮ** *ф. диал. к.* **салындыру**. *Әнә тегендә, өске сәндерәдән аякларын сәлендереп, чем-кара чәчле, чак кына сулга кыйшайган кылыч танаулы, какчарак яңаклы, егерме бишләр тирәсендәге чибәр ир утыра.* М.Кәрим. *Бер канатын сәлендереп, төлкебүреләр белән сугышып йөри шунда...* М.Хәбибуллин

**Сәлендерә төшү** Бераз сәлендерү; ныграк сәлендерү

**Сәлендереп кую** Тиз арада сәленгән хәлгә китерү. *Тарантас эчендә күперелеп кызыл тышлы ястык ята, аның өстенә бизәкле келәм җәелгән, келәмнең бер очы артка, читән тышына сәлендереп куелган.* М.Кәрим

**Сәлендереп тору** Әле, хәзер яки һәрвакыт, гел сәлендерү. *Колакларындагы хәзерге заманның чулпысы кебек колак алкалары болай да зур колакларын басып, сәлендереп торалар.* Г.Исхакый

**СӘЛЕНКЕ** *с. диал. к.* **салынкы**. *Көн бик сәленке иде: күк йөзен кара болыт томалаган, көнбатыш тарафыннан кара болытлар белән бергә күңелгә шом төшкән иде.* М.Хәбибуллин

**СӘЛЕНҮ** *ф. диал. к.* **салыну**. *Озын сандугачлар утырган агач ботакларында карлар таган ясап сәленәләр.* Һ.Такташ. *Татлы илнең татлы Сәлимәсе, Синең «м»дә минем күңелем сәленә.* Г.Кутуй

**СӘЛЛӘ** *и.* Чалма. *Күрер күзгә муллa сымак солтанатмыз – сәлләне килештереп урасак без.* М.Акмулла. *Башында зәңгәр сәллә, өстендә ак җилән, аягында кәвеш.* Н.Сәфәрев

**СӘЛПЕРӘЮ** *ф.* 1) Искерү, тузу, таушалу яки башка сәбәптән бераз салынып төшү. *Ишектән керүгә, ул гөрес итеп табуреткага утырды һәм читләре сәлперәеп төшкән фетр эшләпәсен салып, җилләнергә тотынды.* Ә.Еники. *[Гайзулла] Тамырлары кабарып торган кул аркасы белән сакалын сыйпаштырды, сәлперәйгән киез эшләпәсен күтәрә төшеп, җыерчыклы маңгаен ачыбрак куйды.* М.Хәбибуллин. *Хәтта аның сәлперәйгән җилкәне дә*

*күләгә бирә торган чаршаудан башкага дәгъва итә алмый иде.* А.Тимергалин

2) Шиңеп салынып төшү (үсемлек тур.). *Алмагачларның яфраклары сәлперәеп төшкән.* И.Гази. *Шунда төшкән эзләр дә җәенкеләнеп саектылар, уртадан сәлперәеп салынган әрекмән яфрагына охшап калдылар.* М.Хуҗин

3) Тән тиресе җыерчыкланып салынкылану, салынып тору. *Шәмсүннең кәефе китте. Яңаклары, сәлперәеп, ике якка салынды.* А.Вергазов. *Йомшарткыч маскалар коры, сулган, җыерчыклы тиреләргә файдалы булса, кузәнәкле, сәлперәйгән, сулган тиреләргә үзләндерә торганнары кирәк була, андый маска кузәнәкләрне бөрештерә һәм җыерчыкларны бетерә.* Матурлык нәрсәдә?

4) Чирләү, картаю аркасында хәлсезләнеп зәгыйфьләнү. *Шәймәрдән бабай ул чакта сәлперәйгән карт булмаган әле.* Л.Ихсанова

5) *күч.* Пассивлану, ихтыяр көче китү, төшенкелеккә бирелү, кәеф китү

**Сәлперәя бару** Торган саен ныграк сәлперәю

**Сәлперәя башлау** Сәлперәергә тотыну. *Мондый битлек картая, сәлперәя башлаган тире өчен файдалы.* Мәдәни җомга. *Буявы уңып, сәлперәя башлаган яшькелт кофтасының җиң очлары инде берничә мәртәбә кайтарылып куелса да, беләкләренә таба салынып төшкән иңсәләре белән ул һаман да озын булып күренә.* Безнең гәҗит

**Сәлперәя төшү** Беркадәр, бераз сәлперәю

**Сәлперәеп бетү** Бөтенләй, тәмам сәлперәю. *Сәлперәеп беткән, бер аягы белән инде кабер бусагасына баскан карт белән карчык.* Ә.Рәшит

**Сәлперәеп калу** Ниндидер вакыйгадан, тәэсирдән соң сәлперәйгән хәлгә килү. *Вил Садриевич йөрәк белән авыргалый иде. Теге хәлләрдән соң (анонимка) сәлперәеп калды.* Х.Камалов

**Сәлперәеп китү** Көтмәгәндә, кинәт сәлперәю

**Сәлперәеп тору** Гел сәлперәйгән хәлдә булу. *Шәлпек иреннәре, яше олыгаюына карамастан, һаман да шул килеш: чәй эчкәндә, стаканның ъртысына диярлек җитеп сәлперәеп торалар.* М.Хуҗин

**СӘМА** *и. гар. иск.* Күк, күк йөзе. *Сәмаларга ашу*

**СӘМАВИ** *с. гар. кит.* 1) Күктән иңә торган. *Кайда сәмави яктылык Берлә янган идеалымның Сихерле шәүләсе!* Һ.Такташ. *Сәмави китаплар*

2) Күктәге, галәм киңлегендәге, шуңа хас. *Бу соңгы сүзләр гүя әллә нинди сәмави бер аһәң, җазибәле бер нәфес белән сөйләнде.* Ш.Камал. *Юк, әлеге сүз тезмәсен шагыйрь үзе язмагандыр, бу сәгадәтле мизгелдә ул үзен онытткандыр, ниндидер сәмави көч аның тел коесына тылсымлы сулышын гына өргәндер кебек.* М.Галиев

3) *иск. күч.* Хыялый, абстракт, чынбарлыктан аерылган; буш. *Шигырь язмак белән шагыйль диләрме? Сәмави сүз! Халык аңлар микән соң?* Г.Тукай

4) *күч.* Чиксез матур, күңелгә якын. *[Шагыйрь – ирекtән мәхрүм чибәр кызга:] Кемгә соң ләззәт синең табышың, сәмави сүзләрең?* Н.Исәнбәт

**СӘМӘН** *и. гар. гади с.* Акча, пул. *Рәсем ясый алуында шик бар, билгеле, сәмән төртсәң, андый гына «шедевр»ны Бауман урамында утыручы рәссамнар да әвәләп бирәләр.* Х.Ибраһим. *Ә кемнәрдер читкә (Мәскәүгә һ.б. зур калаларга) сезонлы эшкә китеп, сәмән ягын тулыландыруны кулай күрә, берешләре һөнәрчелек белән шөгыльләнүне үз иткән, сату-алу белән йөрүчеләр дә бар.* Мәдәни җомга

**СӘМӘНДӘР** *и. фар. к.* **саламандра**. *Вә сәмәндәр очраса да, канаты, койрыгы көеп, бикарар булыр.* К.Насыйри

**СӘМӘНЛЕ** *с. гади с.* Акчалы, сәмәне булган. *Эш шунда ки, угрылар кыйммәтле машина белән йөрүче сәмәнле кешеләрне тиз ачыклый.* Безнең гәҗит

**СӘМИХ** *и. гар.* Кайбер үсемлекләрнең сәнәгатьтә, медицинада кулланыла торган куерган ябышкак суты. *Кабаклары шешенке күзләре ачылмый гына Әскәрнең, такырлана башлаган киң маңгае өстәл лампасыннан төшкән саран яктылыкта җансыз балавыздай ялтырый, сәмих сагызы төсле куе төкерәгә ап-ак батист мендәргә тамган.* А.Гыйләҗев

**СӘМРУГ** *и. фар.* 1) Фарсы мифологиясеннән төрки халыклар, шул исәптән татар фольклорына кергән зур, көчле һәм бик зур тизлек белән оча торган кош образы (күп очракта бәхет символы)

2) *күч.* Россия гербындагы ике башлы бөркет. *Рәхим бай яшел-сары кәгазьгә машинка белән төшерелгән юлларны, кәгазьгә сугылган ике башлы сәмруг кош сурәтендәге мөһерне, бит тутырып куйган имзаларны күрде дә коелды да төште ---.* М.Хәбибуллин

◊ **Сәмруг кош** *к.* **сәмруг**. *Идел күперennән ике башлы сәмруг кош сурәте мәтәлеп төшә, көчләп тагылган исем шундук телдән югала, халык аны Кызыл күпер дип атый башлый, чөнки, озак та үтми, күперне кызыл кан түгеп якларга туры килә.* И.Низамов. *Бер якларына ике башлы сәмруг кош сурәте төшерелгән.* Г.Мөхәммәтшин

**СӘМУМ** *и. гар.* Гарәбстан һәм Төньяк Африка чүлләрендә, давылдай башланып, тиз узып китә торган үтә коры, көчле кайнар җил. *Яки өстегездән ком бураны, Көчле сәмум җиле истеме? Истеме?..* Һ.Такташ. *Бу куыш безне зәһәр сәмумнан саклый алмаса да, баш өстендә түбә, ян-якларда стена булу ничектер тынычландыра иде.* А.Тимергалин

**СӘНӘ** I *кис. к.* **сана**. *Жир нигә әйләнә, ник моңсу бу җирдә, әйтсәнә?* З.Мәхмүди. *Төшләремә кермәсәнә, Ак көртләргә күңелемне төрмәсәнә, Салкын боздай йөрәгемне җылытсана, Көзге яфрак кебек сары булмасана!* А.Нәҗми

**СӘНӘ** II *и. гар. иск.* Ел. *Соңгы сәнәләрдә бунчак фәэзыйләтле, бунчак газамәтле бер вакыйга бер кемсәгә дә насыйп булмаган иде.* Г.Толымбай. *Ләкин инде аның күңеле бер дә ала торган нәрсәдә түгел, бәлки, моннан биш сәнә мокатдәм булган вә үткән хатирәләрне актаруда иде.* М.Гафури

**СӘНӘГА** *и. гар. к.* **сәнәгать**. *Тукучылык сәнәгасе*

**СӘНӘГАТЬ** *и. гар.* Халык хуҗалыгының җитештерү чараларын, куллану әйберләрен эшләп чыгара, чимал эшкәртү, җир асты байлыкларын табу

белән шөгыльләнә торган тармагы. *Оешмада катнашучыларның Советка каршы эшчәнлекләре сәнәгатькә (промышленность), авыл хуҗалыгына, мәдәниятькә зыян-зәүрәт салудан гыйбарәт.* Р.Мостафин. *Россиядә җирләр, белүебезчә, торак пункт җире, авыл хуҗалыгы, урман һәм су фонды, махсус саклanучы территория җире, запас җир, сәнәгать, транспорт җире кебек категорияләргә бүлеп йөртелә.* Шәһри Казан

**СӘНӘГАТЬЛЕ** *с.* Сәнәгате булган. *Компаниянең (фирманың) бер төсле товарларны өч төрле кулланучыга атап җитештерүе ихтимал: югары үсеш алган, камил, сәнәгатьле ил өчен, талымсызрак илләргә тәгаенләнгәне һәм иң түбән сыйфатлысы – үсеп килүче яисә бетеп баручы ил өчен.* Татар мөселман календаре

**СӘНӘК** *и.* Озын сапка утыртылган тимер башы ике, өч яки аннан да күбрәк япьле, печән, салам, тирес һ.б.ш. нәрсәләрне өю, элэктереп күтәрү һ.б.ш.лар өчен хезмәт итә торган авыл хуҗалыгы коралы. *Тиле Галиәхмәтнең кулында... агач саплы тимер сәнәк иде!* Р.Низамиев. *Менә хәзер дә ике япьле агач сәнәк белән печән тарата.* Р.Мөхәммәдиев. *Тырма, сәнәкләрен атып бәреп, кыз-кыркын да күләгәле якка тәгәрәде.* И.Низамов

◊ **Сәнәк белән су сөзү** Мәгънәсез, кирәкмәгән эш эшләү. **Сәнәк күтәрү** Сәнәк белән һөҗүм итү. *Нәрсә дип мин бу эт мужиклар арасына килдем? --- Балта, сәнәк күтәрерләр дә килеп үтерерләр! [дип уйлады карчык].* Г.Ибраһимов. **Сәнәккә күтәрү** Сәнәк белән чәнчеп үтерү. *Әле кичә берәү сөйләп торды: – Патшалары мәтәлеп төште инде, хәзер байларын тимер сәнәккә күтәрергә вакыт, – ди.* И.Гази. **Сәнәктән көрәк булу** *шелт.* Гади халык арасыннан чыгып күтәрелгән мин-минлекле кешегә карата әйтелә. *Сәнәктән көрәк булган, пумаладан куак булган.* Әйтем. *Кырык буын шәехләр нәселенә барып тоташа торган хикмәт ияләре дә, сәнәктән көрәк булган надан ертлачлар да яшн Зәйтүганда.* Ф.Бәйрәмова

**СӘНӘКЛЕ** *с.* 1) Сәнәк тоткан, сәнәк белән коралланган. *Ул, сәкедән кузгалып идән уртасына басты да, үрелә биреп, урамга – анда шаулаган күсәкле, сәнәкле мужиклар ягына карады.* Г.Ибраһимов

2) Сәнәк тотып эшләнә торган. *Сәнәкле эштә эшләү*

3) *тар. к.* **сәнәкче** (*2 мәгъ.*). *Фронтын айкадым, ачлыгын кичердем, сәнәклеләрнең фетнәсен бастыруда катнаштым.* А.Расих

**СӘНӘКЛЕК** *с.* **1.** 1) Сәнәк ясау өчен билгеләнгән, сәнәккә яраклы булган. *Кыштан хәзерләп, чатын чатка аерып тарттырып куйган егермеләп сәнәклек агачыбыз бар.* Г.Галиев

2) Бер сәнәккә элэктереп күтәрә алырлык күләмдә булган. *Күбә бер сәнәклек печән өемен белдерә.* Т.Хәйретдинова. *Ярый ла бөтен югалту өч төп бәрәңге я булмаса ике сәнәклек печәнгә генә кайтып калса, ә менә дәүләтләр арасында җир бүлешү сугышлар, канкоешлар да китереп чыгара.* Шәһри Казан

**2.** *и. мәгъ.* Сәнәккә яраклы материал. *Кара урманда сәнәклек япьле агач табалмыйм.* Табышмак. *Су буеннан сәнәклек алып кайту*

**СӘНӘКЧЕ** *и.* 1) Сәнәк белән эшләүчеләр. *Кибән куючы сәнәкчеләр*

2) *тар.* 1920 елның фераль-март айларында Идел-Урал төбәгендә крестьяннарның баш күтәрүендә катнашучы. *Егерме беренче ел дәвамында тайга урманнарында хөкем кылып йөргән бандалар тар-мар ителгәч, кулак коткысына бирелеп фетнәчеләргә, сәнәкчеләргә кушылып киткән ярлы-ябага, байтак вакыт урманнарда качып-посып йөргәннән соң, берәм-берәм авылларына кайттылар да песием булып кына яши башладылар.* Я.Зәнкиев. *Комиссар Бородин сәнәкчеләр фетнәсенә каршы көрәштә алгы сафта була.* С.Шакир

**СӘНГАТИ** *с. к.* **сәнгатьчә**. *Ләкин соңгы 2,5–4 мең ел эчендә кешелек җәмгыяте сәнгати фикерләү өлкәсендә искиткеч зур адым ясый.* К.Гыйззәтов. *Тавышның салмак кына күтәрелә яки төшә алуы – әһәмиятле сәнгати чара ул.* Г.Нуриев

**СӘНГАТИЛЕК** *и. к.* **сәнгатьчәлек**. *Сәнгатилекнең объектив функциясе сәнгатьтәге миллилекнең башка элементларын бергә укмаштырудан гыйбарәт.* К.Гыйззәтов

**СӘНГАТЬ** *и. гар.* 1) Дөньяны эстетик танып белү, иҗтимагый аңның чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыра торган формасы. *Сәнгать – кешеләрнең рухи продукты һәм алар өчен рухи азык та.* Философия

2) Чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләү осталыгы. *Анда борынгы майя һәм инк халыкларының гаҗәеп сәнгать әсәрләре, манаралары, калалары турында язылган иде.* М.Маликова. *Декадага әзерлек чорында киң массаның үзешчән активлыгы үсүе нигезендә, җыр сәнгате һичшиксез яңа күтәрелешкә ирешергә тиеш.* Ә.Давыдов

**СӘНГАТЬКӘР** *и. гар.-фар.* Сәнгать өлкәсендә эшләүче, берәр сәнгать остасы. *Бу йөзекне киеп йөрергә, Фатыйма ханым, сездән дә лаек сәнгатькәр юктыр.* Р.Батулла. *Ничектер әзрәк булган кебек тоела күренекле сәнгатькәрләргә.* Т.Нәҗмиев

**СӘНГАТЬЛЕ** *с.* **1.** Сәнгать таләпләренә туры китерелгән; нәфис, матур, югары сыйфатлы. *Менә шундыйлардан – педагогия училищелары өчен татар әдәбияты, сәнгатьле уку һәм татар балалар әдәбияты буенча программалар беренче басылып чыкты.* А.Әхмәдуллин. *Сәнгатьле сөйләм*

**2.** *рәв. мәгъ.* Сәнгать таләпләренә туры килерлек итеп. *Әйдә, сәнгатьле итеп укып күрсәт әле шигырьне.* Р.Галиуллин

**СӘНГАТЬЛЕЛЕК** *и.* Сәнгатьле булу. *Соңгы эшләргә югары сәнгатьлелек дигән бөек бер нәрсә җитмәгәне һаман ныграк, ачыграк күренә бара иде.* М.Вәли-Барҗылы. *Кайчакта шигърияттнең бөеклеге сәнгатьлелек ягыннан түгел, нинди шартларда язылу белән бәйләнә.* Р.Зәйдулла

**СӘНГА́ТЬЧӘ** *с.* **1.** Сәнгать таләпләренә, закончалыкларына җавап бирә торган. *Мәсәлән, музыкада сәнгатьчә гомумиләштерүнең нигезен милли үзенчәлекле музыка теле тәшкил итә.* К.Гыйззәтов. *Картаймыш көнендә*

*кешенең сәнгатьчә фикерләве йомшый, зәгыйфьләнә.* А.Тимергалин

**2.** *рәв. мәгъ.* Сәнгать таләпләренә туры китереп. *Шуңа күрә, сүзләргә музыка язылганда, аларның сәнгатьчә образлы булуларына һәм, барысыннан да бигрәк, эмоциональ көчлелек тудыра алуларына игътибар ителә.* Ж.Фәйзи. *Һәр ике шигырь сәнгатьчә эшләнгән, аңлаешлы, кайсы кемгә күбрәк ошый, бусы, бәлки, зәвык эшедер.* С.Сөләйманова. *Ул үгетләрен дә, мораль чисталыкка, сәяси сизгерлеккә өйрәтүен дә, артык нык сиздермичә, ләкин күңелгә мәңгегә сеңеп калырлык итеп сәнгатьчә тәкъдим итә белә.* Р.Миңнуллин

**СӘНГА́ТЬЧӘЛЕК** *и.* Сәнгатьчә булу. *«Җил исә, агач шаулый» дигәндә берниндиe сәнгатьчәлек тә калмый, ди ул.* Х.Сарьян. *Ягъни драматургия тарихын яңадан барлаганда һәм өйрәнгәндә, аның сәнгатьчәлек ягыннан да алга үсеш тарихы булуы истә тотылырга тиеш.* А.Әхмәдуллин

**СӘНГАТЬЧЕ** *и.* Сәнгать белгече; сәнгать белеме белән шөгыльләнүче фән эшлеклесе. *Культуролог, сәнгатьче Җәннәт Сергей Маркус, мәчетне ишүләре – бөтен Евразия мәдәни мирасы өчен зур югалту, дип белдерде.* Безнең гәҗит

**СӘНДЕРӘ** *и.* 1) Авыл өендә түшәмнән түбәндәрәк тактадан ясалган ятак яки әйберләр кую урыны. *Шәвәлинең эче һаман да әле вакыт-вакыт каты чурлый, ләкин сәндерәнең җаен аңлап алган Шәвәли мондый чакта борылып ята, шунда сәндерә тактасы шыгырдый, һәм эч чурлавы ишетелми кала иде.* С.Рафиков. *Кичләрен кәҗәләр кетердәтеп печән ашый (абзар башында әзрәк иске печән бар иде), кызы сәндерәдә җылы мичкә аркасын терәп йоклый, ә Һәдия кул эшләре тота.* Г.Якупова

2) Вагон, пароход, казарма, төрмә һ.б.ш. җирләрдә стена буенда биек итеп ясалган йоклау урыны. *Иң өске сәндерәдәге ике карт солдат кына, шинельләрен ябынып, тәрәзәгә карап баралар, гүя теге яктагы кара-зәңгәрлектән нидер шәйләргә тырышалар.* Ф.Галиев. *Солдат вагонының ике яртысына да икешәр кат сәндерәләр ясалган.* М.Кәрим

3) Сарай, лапас кебек каралтыларда печән һ.б. мал азыгы саклау өчен, түбә астында такта яки киртәләрдән эшләнгән киң киштә. *Әмма хуҗабикә буласы бу юан вә тупас зат алдан ук шарт куйды: – Мунчасын ягармын, ашарына пешерермен, әмма йоклавын лапас сәндерәсендә йоклар, җаен табар, сузылып ятар, белəм мин аларны.* Ф.Яхин

4) Каланча кебек корылмаларның югарыда такта түшәп эшләнгән мәйданчыгы. *[Скважина авариясе вакытында] бозлы су верховой сәндерәсенә кадәр күтәрелеп, кешеләрнең өсләренә явып торды.* Ш.Бикчурин

**СӘНДЕРӘЛЕ** *с.* Сәндерәләп эшләнгән, сәндерәсе булган. *Язгы табигать дәрьясына чумган алты сәндерәле вагонда берүзе йоклап яткан буйдак ирнең нинди төшләр күрәсе билгеле инде.* К.Кәримов

**СӘНҖАК** *и. к.* **санҗак**. *Төркия хөкүмәте Искәндәрүн вә Антакья сәнҗаклары халкының зур күпчелеге төрек халкы булуын алга сөреп, Төркиягә кайтарылуын таләп итте.* Г.Исхакый

**СӘП-** Кайбер сыйфатлар белән килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый торган кисәкчә. *Сине теп-тере, сәп-сәламәт кеше итеп күрәсем килгәнгә әйтәм бу сүзләрне.* З.Мәхмүди

**СӘРӘТАН** *и. гар.* 1) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган йолдызлык атамасы һәм шул йолдызлыкның тамгасы; кысла йолдызлыгы

2) Кояш календаре буенча унике айдан торган йолдызлыкның дүртенче ае исеме (22 июньнән 21 июльгә кадәр) һәм шул айда туган кеше

**СӘРБАЗ** *и. фар. тар.* Гаскәри, солдат. *Җаек буендагы башбаштаклыктан файдаланып, крепостька казах ханының сәрбазлары бәреп керә.* В.Имамов

**СӘРБИ** *и. фар. сөйл к.* **сәрви**. *[Илгиз] Гөлчирәне күрү белән шат елмаеп, сәрби агачларыннан иелә-иелә, аның янына йөгерде.* С.Сабиров. *Сәрби агачларының ябышкак бөреләре бүртеп чыга.* Г.Бәширов. *Ләкин алар турыдантуры барып кермәделәр, поликлиника каршындагы сәрби куаклары ышыгында әкрен генә әрле-бирле йөреп тордылар.* М.Насыйбуллин

**СӘРВИ** *и. фар. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күбесенчә мәңгеяшел, кайбер төрләре декоратив максат белән үстерелә торган куак яки вак агач; акация. *Тимер рәшәткә буенда башлары тигез итеп кыркылган сәрви куаклары чәчәк атып утыра.* Г.Әпсәләмов. *Куе чаганлыктан мүкәләп үтәм дә, аяк очларына гына басып, сәрви куаклары артына посам.* М.Галиев

**СӘРВИЛЕК** *и.* Сәрвиләр (күп) үскән урын, сәрви куаклыгы. *Ындыр артындагы сәрвилек*

**СӘРГАСКӘР** *и. фар.-гар. тар.* Гаскәр башлыгы. *713 елда хәлифәтнең сәргаскәре Маслама Хазарстанга яу килә һәм каты сугышлардан соң Тимер капка (бүгенге Дербент) шәһәркальгасын алуга ирешә.* М.Хәбибуллин. *Ибраһим хан үзен зирәк сәясәтче, оста сәргаскәр, сәләтле һәм каты куллы татар дәүләтчесе, хөкемдар итеп таныта.* Ватаныбыз тарихы

**СӘРГӘРДАН** *с. фар. иск. кит.* Кайгылы, боек, төшенке күңелле (чит җирләрдә каңгырып йөрүчеләр тур.). *Шомлы хәбәрләргә ышанып, Исламгол җиренә күчкән беркатлы аталар гына, бөтен малларыннан, барлык балаларыннан аерылып, Кырым, Кавказ таулары арасында күп еллар сәргәрдан булып йөрделәр.* Х.Кәрим

**СӘРДАР** *и. фар. тар.* Башлык, гаскәр башлыгы, командир, башта торучы. *Шәһәр капкасы ачылды да, анда инде аргамак өстенә атланырга өлгергән сәрдар пәйда булды.* В.Имамов

**СӘРДӘ** *и. фар. бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан гөмбәз сыман булып оешкан вак-вак ак чәчәкле, урманда үсә торган күпьеллык үлән; *русчасы:* **сныть**. *Авыл халкы черегән бәрәңге (безнең якта аны «чирука» дип йөртәләр), алабута, сәрдә, балтырган ашап исән калган.* Ә.Исхак. *Түгәрәк күл читен әйләнеп узгач, сукмак сиздермәстән генә бер читкә борыла да, куе куакларга борынын төртеп, аю табаны, сәрдә, балтырган яфраклары астына яшеренә.* Г.Сабитов. *Куе агачлыкта*

*үлән үсмәгән диярлек, ара-тирә аксыл сусыл сәрдәләр генә, кояш эзләп, төрле якка сузылганнар.* А.Гыйләҗев

**СӘРДӘЛЕ** *с.* 1) Сәрдәләр үсә торган. *Ял иткәч, кәҗәгә яфрак җыярга урман эченә кереп киттем. Кычыткан, сәрдәле үләннәрне билдән ерып барам.* Н.Хәсәнов

2) Сәрдә белән катнаш, сәрдә дә булган. *Сәрдәле печән*

3) Сәрдә салып пешерелгән. *Сәрдәле аш*

**СӘРДӘЛЕК** *и.* Сәрдә (күп) үсә торган урын

**СӘРЕН** *с. монг.* Саф, салкынча. *Ләтыйф төсләр, хуш исләр, язгы сәрен яңгырлар, ал-зәңгәр-кызыл-сары-күгелҗем-миләүшә төсләр һәм башкалар.* Ф.Әмирхан. *Язгы эссе көндә яуган ул сәрен яңгырларың, Ямь-яшел хәтфә кебек киң-киң уҗымлы кырларың.* С.Сүнчәләй

**СӘРЕНҖЕ** *с. фар.* Урта Азиядән кайтарыла торган буйлы-буйлы яки аллы-гөлле киҗе-мамык тукыма

**СӘРЕНЛЕК** *и.* 1) Сафлык, чисталык

2) Салкынча, җиләс рәхәт һава

**СӘРКАТИП** *и. фар.-гар.* 1) *иск.* Дәүләт яки җәмәгать оешмасының яисә аерым кешенең гомуми язу-сызу эшләрен башкаручы; секретарь. *Офис бүлмәсе. Рәсүл Идрисович уйга батып утыра. Телефоннан сәркатибенә эндәшә.* А.Гәрәева

2) Җыелыш-утырышларда беркетмә язучы; секретарь. *Рәшит исә тизрәк бу иптәшләренең йомышларын йомышлады да, сәркатибенә беркемне кертми торырга кушып, яңадан Фәнистән әле генә үткәрелгән «тәҗрибә» турында сораштырырга тотынды.* Ш.Алпар

3) Берәр оешманың сайлап куелган җитәкчесе; секретарь. *Шулай бервакытны «Ялкын» журналында җаваплы сәркатип урыны бушады.* Җ.Дәрзаман

**СӘРКАТИПЛЕК** *и. к.* Сәркатип эше

**СӘРКӘШ** *с. фар. иск. диал.* Тискәре, үзсүзле, кире. *Ягъни явыз сәркәш нәфесеңә ихтыяр бирү, даими аның әмерендә булу сине кире юлга тартыр, чөнки янучы ут та төз янмас, бәлки һава агышына мөнәсәбәтле йөрер.* Т.Ялчыгол

**СӘРЛӘҮХӘ** *и. фар.-гар.* 1) Китапның фронтисписы

2) Кульъязманың беренче битендәге бизәк, заставка

**СӘРМАЯ** *и. фар.* 1) Берәр эшне башлап җибәрү өчен төп капитал, акча, төп мая. *Кичен һәркем үз участогында булсын, сәрмая туплагыз, и вәссәлам...* С.Рафиков

2) Гомумән, акча, сәмән. *Эх, сәрмая җитәрлек булса, үзләрен кинотеатрларга чакырыр идем.* А.Расих. *Журналны нәшер итү өчен сәрмая (средство) кирәк булганлыктан, бу әһәмиятле мәсьәләне вөҗүткә чыгаруны башлап җибәрергә сәрмая ягыннан көче җитәрлек булган Әхмәтгәрәй Хәсәниягә йөкләмәләр.* Мирас

**СӘРМӘҮ** *ф. диал.* Капшап, тотып карау, кабалау

**Сәрмәп алу** Тиз арада сәрмәү. *Шул чалкан яткан көе егет, һич тә исе китмәгәндәй, алманы сәрмәп алды да шартлатып ашарга кереште.* М.Кәрим

**Сәрмәп чыгу** Булган берсен сәрмәү. *Аның эченнән дүрт корыч чөй килеп чыкты. Карт чөйләрне җентекләп сәрмәп чыкты.* З.Зәйнуллин

**СӘРПИ** *с.* Тигез колаклы, еракка оча торган. *Аның тугрылыклы актачысын, Казанны алганда, Япанчының бер яраны сәрпи уктан атып үтерде.* Р.Зәйдулла. *Оста мәргән өчен һичбер кыенлык юк, дошман итсә, ул бәкне инде күптән сәрпи ук очына утырта ала иде.* В.Имамов

**СӘРПИНКӘ** *и. к.* **сарпинка**. *Каршы сүз әйтере калмаганга күрә, Фатыйма: – Карале, карт, аннан ары болар, Казан хәтле Казаннан кайтып, буш кул белән килеп кергәннәр, димәсеннәр өчен, теге өч ак сәрпинкә яулык янындагы зәңгәрсу сатин яулыкка төреп, бер-икене генә булса да Гөлҗиһан сабыны да куймасак, әллә ничегрәк чыкмас микән ул? – диде.* Ә.Гаффар

**СӘРХӘБАД** *и. фар. сир.* Начар чир, авыру; сырхау. *Соңгы айларда Бибисага сәер генә сәрхәбад каныкты.* С.Сөләйманова

**СӘРХУШ** *с. фар.* **1.** Исергән, исерек. *Болар тиз арада, күктән йолдыз чүпләү рухы белән әсәрләнеп йөргән сәрхуш галим-галимәләрне кысрыклап, институның «хөрмәтлеләре» рәтендә иң мактаулы урынны алачаклар, билгеле.* Т.Галиуллин. *Бу әлеге дә баягы сәрхуш Самат иде.* З.Фәтхетдинов. *Вилдан яңадан сәрхуш хәлдә күренгәли башлады.* А.Шамов

**2.** *и. мәгъ.* Исерекбаш, исерткеч эчүгә бирелгән кеше. *Төрмәдән кайткан араларында Мөнирҗанның ата сәрхуш булганлыгын онытып өлгермәгәннәр иде әле.* Н.Әхмәдиев. *Теге сәрхушларның кайсысыдыр ачылмаган шампан шешәсен кулыннан төшереп җибәргән, нәгъләт!* З.Фәтхетдинов

**СӘРХУШЛАНУ** *ф.* Исерү, сәрхуш булу. *Ничек кыюлыгы җиткәндер: бервакыт шулай да, үзен җиңеп, сәрхушланып кайткан әтисенең янына ук килеп утырды ул.* Р.Низамиев. *Яшәүләренең бөтен кызыгы – кайдан да булса, нәрсә дә булса табып исерү, сәрхушлану.* Т.Миңнуллин

**Сәрхушлана башлау** Сәрхушлану билгеләре белену

**Сәрхушланып алу** Тиз арада сәрхушлану. *Ә ирләрнең күбесе инде сәрхушланып алганнар да, әйләнә тирәли утырып, берсеннән-берсе тозсызрак сүзләр әйтешә-әйтешә кәрт сугалар.* Җ.Дәрзаман. *Шактый сәрхушланып алгач, Акболыт Сарытаудагы бу дустына эч серләрен дә бушатып куйды.* Р.Гарипов

**Сәрхушланып бетү** Бөтенләй, тәмам сәрхушлану

**Сәрхушланып йөрү** Озак сәрхушланган хәлдә булу. *Шулай да аның эш вакытында «сәрхушланып» йөрүе берәүгә дә сер түгел.* Җ.Дәрзаман

**Сәрхушланып китү** Кайсыдыр бер моментта сәрхушлану

**СӘРХУШЛЫК** *и.* Исерек булу, исереклек. *Аларның сәрхушлыгыннан сиңа ни зыян да, миңа ни зыян. Аның каравы алар белән идарә итү җиңел.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу мизгелдә Рәхиләнең сәрхушлыктан миңгерәүләнгән баш мие күзәнәкләре Исхак исемле берәүне хәтерләргә тырышып җәфаланды.* Г.Галиев

**СӘТЫР** *и. гар. иск. кит.* Язуда юл. *Шул сәтырларны язучының унлап әдәби әсәре, язылганнарына биш-алты*

*ел үтсә дә, басылмый торалар.* Г.Исхакый. *Сез конкрет вакыйгаларны күз уңында тотып яздыгызмы ул сәтырларыгызны?* Р.Батулла

**СӘҮДӘ** *и. фар.* Сату-алу эше, кәсебе; тиҗарәт. *Барыннан да ныграк гарьләндергәне тагын шул иде: Гөлҗиһан аны үзенең сәүдә эшенә якын җибәрми, дилбегәне үз кулыннан ычкындырмый.* А.Расих. *Касса урнашкан сәүдә конторасының тышкы ишеген ачарга ярый торган ачкыч булып чыкты ул.* М.Насыйбуллин

**СӘҮДӘГӘР** *и. фар.* 1) Хосусый сәүдә белән шөгыльләнүче, сәүдә итүче. *Иртә берлән кайнамакта бу базар: Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр. Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала, Берсе алдый, шунда берсе алдана.* Г.Тукай. *Шул дәверләрдә үк Казан Русиянең Мәскәүдән соң беренче бай шәһәре булып, татар сәүдәгәре бөтен Русия базарларында икенче урынны тоткан.* Г.Исхакый

2) Гомумән сәүдә өлкәсендә эшләүче зат. *Куркак сәүдәгәр файда күрмәс, зарар да күрмәс.* Мәкаль. *Мин дә синең гади сәүдәгәр булуыңа ышанмыйм.* Г.Тарханова. *Бу – Мамайның Италия сәүдәгәрләре белән мәҗлес коруларына ишарәләп, чеметеп алуы иде. Ләкин угы төзәгән җиргә тимәде.* Казан утлары

**СӘҮДӘГӘРЛЕК** *и.* Сәүдәгәр кәсебе; сәүдәгәр булу; сәүдә итү шөгыле. *Дөньяда минем иң яратмаган шөгылем – сату-алу, ягъни сәүдәгәрлек.* Ф.Яруллин. *Дамир --- беренче шәхси кибетен ачкан, хәзер аларның саны унга җиткән, һәм сәүдәгәрлек аның төп шөгыленә әйләнгән.* Ф.Садриев

**СӘҮДӘ́ ИТҮ** *ф.* Сәүдә эше, алыш-биреш белән шөгыльләнү, сату-алу. *Сәүдә итү – җирдә иң борынгы һәм һәрвакыт хөрмәткә лаек һөнәр!* А.Хәсәнов. *Габдрахман хәзрәт урта мәхәлләнең имамы булган, ләкин атасы Хәбибрахман нишләптер ата-баба юлыннан китмәгән, иген игү, мал асрау, шуның өстенә сәүдә дә итүне артыграк күргән.* Ә.Еники

**СӘҮДӘЛӘШҮ** I *ф. сир. к.* **сатулашу**. *Дидә, без бик яхшы эт баласы сатып алдык, бәя дә түгел, әбием сәүдәләшеп, юньгә алды.* В.Ильясов. *Юк, монда Совет властеннан сәүдәләшеп тиеннәр алу гына түгел, бәлки Совет властена дошманлык исе аңкый...* Казан утлары

**Сәүдәләшеп алу** Бераз сәүдәләшү; берара сәүдәләшү. *Базарда мал бәясен сәүдәләшеп алу*

**Сәүдәләшеп йөрү** Әледән-әле, даими сәүдәләшү

**Сәүдәләшеп тору** Сәүдәләшү процессында булу; һәрвакыт, өзлексез сәүдәләшү. *Ул китапчыларга сатып, сәүдәләшеп тормый; теге комсызлар үз ирекләре белән, шәфкатьләре килеп, күпме хак куялар, шуңа Тукай риза була.* Г.Халит

**СӘҮДӘЛӘШҮ** II *и.* Сәүдәләшү гамәле, шуның процессы. *Җанлы курчак сатучы һәм алучы аталар арасында сәүдәләшү башланды: – Юк, Зәйнетдин абзый, мәһәр биш йөз тәңкә!* Ф.Әмирхан

**СӘҮДӘЧЕ** *и.* Сәүдә өлкәсендә эшләүче, сәүдә эшләре белән шөгыльләнүче, сәүдә алып баручы. *Соңгы елларда хәл үзгәрә башлады: бер яктан, --- сәүдәчеләр һәм кәсепчеләрнең мөстәкыйльлегенә берникадәр юл куелу, икенче яктан, --- гомумән дә демократия, хәбәрдарлыкның борын төртә башлавы реклама өлкәсенә дә йогынтысыз калмады.* Казан утлары

**СӘФӘР** I *и. гар.* Сәяхәт, ерак юл. *Сәфәргә чыккан ялгыз кырмысканың максаты нык: ул ничек тә тиешле урынга барып җитәргә һәм оясына тәмле ризык алып кайтырга тиеш.* Г.Гыйльманов. *Читкә киткәннәр туган якларына сәфәргә кузгала.* И.Низамов. *Авыл халкы үзләре тәрбияләп тергезгән кошны кул болгап, хәерле сәфәр теләп озатып кала.* А.Тимергалин

◊ **Сәфәр китү** *к.* **сәфәр чыгу**. **Сәфәр тоту** Берәр җиргә юнәлү, шул якка чыгу. *Шулай итеп, Мурманскига сәфәр тоткан Шәһинур, ярты юлдан борылып, ике-өч көн дигәндә киредән туган авылына кайтып төште.* Р.Низамиев. *– Һәй, корабтагылар, кай тарафка сәфәр тотасыз? – дип кычкырдылар алдагы көймәдән.* М.Хәбибуллин. *Сукыр солдат бик ачык кеше булып чыкты. Безнең кая сәфәр тотуыбызны, нинди максатлар белән йөрүебезне белеп алгач, тагын да ачыла төште.* А.Хәсәнов. **Сәфәр чыгу** Сәфәргә, юлга чыгу. *Иртәгә сәфәр чыгабыз дигәндә, аның янына, көтмәгәндә, анасы килеп керде.* М.Хәбибуллин. *Ниһаять, уйлаганның өченче көнендә Хөсәен өстенә мәрхүм этисенең толыбын киде дә, ямщик атына утырып, ерак юлга сәфәр чыгып китте.* А.Расих. *Миңнурый белән Булат бүген генә торага, Дәүләтша әкәләрен йолып алу әмәлләрен эзләргә сәфәр чыкканнар иде.* Я.Зәнкиев

**СӘФӘР** II *и. гар. к.* **сафәр**. *Сәфәр ае кергәнче булса иде.* Г.Ильяси. *Мин 1947 елның 4 гыйнварында, зәмһәрир суык вакытта, сәфәр аенда туганмын.* Р.Вәлиев

**СӘФӘРДӘШ** *и.* Сәфәрдәге юлдаш, бергә сәфәрдә булучы кеше. *Самат та сәфәрдәшләре янына килеп басты. – Җитәбез!..* Б.Камалов. *Өшәнеп калган Юрийның сәфәрдәше Глеб дуамал булып чыкты: барча сугышчыларына һөҗүмгә ташланырга әмер бирде.* В.Имамов

**СӘФӘ́Р ИТҮ** *ф.* Ерак юлга чыгып китү

**СӘФӘ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **сәфәр итү**. *Казах даласында сәфәр кылып йөргәндә бер йолага шаһит булган икән дәрвиш, шул хакта Караморза имамга сөйләгән.* Г.Якупова. *Күптән түгел миңа Сүриягә сәфәр кылырга туры килде.* Татар мөселман календаре

**СӘФӘРЧЕ** *и.* Сәяхәтче, юлчы, сәфәрдә йөрүче. *Авыл арасында көлешепуйнашып, сикергәләп барган сәфәрчеләр, ындыр коймалары да ераклаша башлагач, юашланып, тынып калдылар.* Я.Зәнкиев. *Баян баһадир, Сәлим хан боерыгы белән, сәфәрчеләрне озатырга йөз азат алды.* М.Хәбибуллин

**СӘФИЛ** *с. гар. иск.* Түбәнлеккә төшкән, хурлыкка калган кеше. *Шулай янсам, ни булды, төшми җиргә якынлашмыйча һәр мәгъру сәфилгә.* Г.Тукай

**СӘФИЛӘ** *с. гар.* Сәфил хатын-кыз. *Кагылып-сугылып йөри торгач, танышлары аркылы ишетеп, үзе кебек сәфилә вә бәхетсез хатыннар белән шырпы фабригына эш эшләргә барып керде.* М.Гафури

**СӘФИР** *и. гар. тар.* Илче, тулы хокуклы вәкил. *Хәзер сезгә ул Указны патша хәзрәтләре сәфире Жихарев әфәнде игълан итәр.* В.Имамов

**СӘХӘР** *и. гар.* 1) Төннең өчтән өченче – соңгы өлеше, таң алды вакыты. *Җомга көнгә каршы, сәхәр вакытында торып, нәфел намазы укып яткач, гомеремдә булмаган бер хәл вакыйг булды.* Г.Толымбай. *Сәхәр вакытында менә шулар белән [борчак, фасоль, майсыз ит, балык, сөт ризыклары, йомырка] тукланырга кирәк тә инде.* Мөселман гаиләсе календаре

2) Мөселманнарның уразада таң атканчы ашый торган иртәнге ашы. *Бу хатын әйтте: «Тукта, бу бик яхшы эш икән, бер көн руза тотаемчы», – дип ният итте, сәхәр ашады, ярты көн руза тотты да карыны ачты.* К.Насыйри. *Элеонора җиңги колхоз амбарына сәхәргә тиешле онны алырга чыгып китте.* А.Хәсәнов

**СӘХИФӘ** *и. гар. кит.* 1) Китап, дәфтәр, журнал, газет һ.б.ш.ның бите. *Әйтергә яраса, бу сәхифәләр минем тәрҗемәи хәлемнән гыйбарәт булып, мин монда баштан үткән эшләрнең җанга тәэсир иткәннәрен, вакыйгаларның мөһим булганнарын яздым.* М.Гафури. *Шундый зур-зур урыннарда эшләүче, исемнәре гәҗит сәхифәләреннән, сурәтләре җирле телевидение каналларыннан төшмәгән кешеләр белән бер табын артында --- утырудан ничек баш тартасың, ди.* Р.Мөхәммәдиев

2) Газет-журнал, җыентык һ.б.ш. басмада билгеле бер темага багышланган бит, бүлек, өлеш. *Җәмәгатьчелекнең игътибарын табигатьнең пычрануы проблемасына юнәлтүгә багышланган сәхифәне җир асты хәзинәләре тар-мар ителүен ассызыклаудан башлыйк.* Шәһри Казан. *«Хроника» сәхифәсендә иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгаларын объектив һәм оператив яктырту.* Казан утлары

3) *информ.* Нинди дә булса веб браузер ярдәмендә ачыла торган документ яки Интернеттагы мәгълүмат ресурсы. *Темалары һәм дизайннары уртак берничә сәхифәдән сайт оештырыла*

4) Тапшыруның уртак темага караган өлеше; рубрика. *Музыкаль сәхифә. Балалар сәхифәсе*

5) *күч.* Гомернең, тормышның, нәрсәнеңдер үсешенең билгеле бер чоры, шул чордагы хәлләр, күренешләр. *Гомер китабының яңа сәхифәләрен үз кулы белән ачты.* М.Насыйбуллин. *Алда китерелгән глобаль тарих сәхифәләрендә бу хакта ап-ачык әйтелә.* С.Шәмси. *Рентген астрономиясе Галәмдәге физик процессларны өйрәнүдә яңа сәхифә ачып җибәрде.* Галәм. Җир. Кеше

**СӘХНӘ** *и. гар.* 1) Тамаша күрсәтелә торган махсус мәйдан. *Сәхнәдә утырган музыкантларга нәрсәдер аңлата иде Яруллин.* М.Латыйфуллин. *Әйтерсең болар әле генә нindидер цирк сәхнәсеннән төшкәннәр дә бу бакчага килеп кергәннәр һәм андагы уеннарын һаман дәвам иттерәләр иде...* Ш.Маннур

2) Театр эше, артист эшчәнлеге; театр белән бәйле өлкә. *Бу дәвердә кытайлар музыкасы яңа жанрларга байый, шул исәптән музыкаль драма жанры барлыкка килә, тагын да активрак рәвештә фольклор өйрәнелә, аның элементлары сәхнә әсәрләрендә файдаланыла.* К.Гыйззәтов. *Шуңа күрә, инструктор итеп алынгач, миңа сәхнәдән китеп торырга туры килде.* Т.Нәҗмиев

3) *күч.* Берәр эшчәнлек өлкәсе. *--- Туфан берничә елга шигърият сәхнәсеннән югалып тора: биштәрен аркасына асып, ил буйлап сәяхәткә чыгып китә, күзәтә, өйрәнә.* Т.Галиуллин

◊ **Сәхнә арты** 1) Театр коллективының эчке тормышы; 2) Нindидер эшчәнлекнең күпчелек кеше өчен билгесез ягы. **Сәхнәгә кую** Сәхнәләштерү. *Хәмзә исемле егет, революцион тарих китапларына нигезләнеп, берсеннән-берсе фаҗигалерәк драмалар яза, үзе үк режиссёр булып, аларны сәхнәгә куя, үзе үк җаны-тәне белән бирелеп, төп рольләрне башкара иде.* М.Әмир. *Драматургның үзе язып, үзе шушы әсәрдә уйнап, үзе үк әлеге әсәрне сәхнәгә куюы – театр тарихында сирәк хәл.* К.Гыйззәтов. **Сәхнәгә менү** *к.* **сәхнәгә чыгу**. *Аның бу тавыш, бу көйләрдән хәбәрсезлек вә бу акцент белән сәхнәгә менүе – бик урынсыз, бик күңелсез бер җөрьәт.* Ф.Әмирхан. **Сәхнәгә чыгу** 1) Артистлык эшен башлап җибәрү; 2) Сәхнәдә куела башлау (әсәр тур.). **Сәхнәдән төшү** 1) Театрдан, сәхнә эшеннән китү; 2) Сәхнәдә куелмый башлау (әсәр тур.). *Кайбер даһи операларның либреттолары начар булган өчен сәхнәдән төшерелүе яки яңа либретто язылуы – күз алдындагы фактлар.* М.Җәлил

**СӘХНӘДӘШ** *с.* Театрда, сәхнәдә бергә эшләүче, чыгыш ясаучы. *Шулчак хуҗабикә сүз алды: – Кадерле кунакларым, сәхнәдәшләрем, балаларым!* Р.Батулла

**СӘХНӘЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Драматургиягә караган берәр сәнгать әсәрен театр өчен яраклаштыру, сәхнә әсәренә әйләндереп сәхнәгә кую. *– Спектакльне нинди сценарий буенча куярга ниятлибез соң? – дип сорады Таймас, үзенең соңгы шикләрен тарату өчен. – Тукай әкияте буенча гына сәхнәләштерә алмассыз ич.* А.Тимергалин

2) Берәр күренеш, шәхес, хәлмөнәсәбәтләр һ.б.ш.ны сәхнә әсәрендә объект итеп алу, нәрсәне дә булса тамаша итеп күрсәтү. *Ватан сугышы эпизодларын сәхнәләштерү*

**Сәхнәләштерә бару** Даими яки регуляр рәвештә сәхнәләштерү

**Сәхнәләштерә башлау** Сәхнәләштерергә тотыну

**Сәхнәләштереп бетерү** Барысын да сәхнәләштерү

**Сәхнәләштереп килү** Күптәннән бирле даими сәхнәләштерү

**Сәхнәләштереп тору** Даими яки регуляр рәвештә сәхнәләштерү

**СӘХНӘЛЕ** *с. к.* Сәхнәсе булган; нindидер сыйфатларга ия сәхнәсе булган. *Мөдәррис исә бер атна эчендә, шигырь сөйләр өчен, сәхнәле итеп, иркен сарай корып куйган.* М.Галиев

**СӘХТИЯН** *и. фар.* **1**. Кәҗә яки сарык тиресеннән эшләнгән юка һәм йомшак күн. *Ә тау башында җиде кыз Сыктыйдыр сыман һаман: «Сәхтиян кимәс наз идем, Чабата тапмай барам».* Г.Морат

**2**. *с. мәгъ.* Шундый күннән эшләнгән яки шуны кушып тегелгән. *Шунда*

*гына Әбүзәр абзый аның кулындагы кызыл сәхтиян тышлы папкага игътибар итте.* Г.Әпсәләмов. *Солтан үзен Шәяхмәт абыйсы кебек шомырт кара мыеклы, биек сәхтиян итекле, буйдан-буйга ак сәдәп тезеп чыккан кара сатин күлмәкле гайрәтле егет итеп күз алдына китерде.* Г.Ахунов. *Җайдагы – сәхтиян читек кигән, көязлеге бөтен торышыннан сизелеп торган, нәсел тамыры борынгы морзаларга тоташкан чибәр ир-егет булыр.* М.Галиев

**СӘЯСӘТ** *и. гар.* 1) Хакимиятнең, иҗтимагый төркемнәрнең халыкара мөнәсәбәтләрдә, дәүләтнең эчке эшләре өлкәсендә үзләренең ихтыяҗ-мәнфәгатьләрен тормышка ашыру юлындагы эшчәнлеге. *Ил сәясәте, дөнья хәлләре үзгәрде, дөнья белән бергә үзебез дә, Конституциябез, законнарыбыз да үзгәреш кичерде.* Мәдәни җомга

2) Нәрсәнедер хәл итүдә, идарәдә һ.б.ш.да таянылган төп принциплар, кагыйдәләр, карашлар системасы. *Татар ирләренең гаиләдә кадерсез булып яшәвендә, күбесенең тәмәкегә, аракыга тартылуында заман сәясәтенең дә гаебе зурдыр, дип уйлыйм.* Э.Шәрифуллина. *Икенче төрле әйткәндә, Тимер бәк юлында торган һәр кешене төрле ысуллар белән алып ташлау сәясәтен эзлекле рәвештә үткәреп килә.* С.Шәмси

**СӘЯСӘТЧЕ** *и.* Сәясәт эшлеклесе; сәясәт өлкәсендәге әһел. *Шулай итеп, ул, зирәк сәясәтче булуы аркасында, кинәт зур дәрәҗәгә ирешә.* С.Шәмси. *[Төш юраучы:] Гел әйтәм аны, әниләр – депутатлардан да шәбрәк сәясәтче!* А.Гәрәева. *Татарстан халкы хәзер аны шагыйрь итеп кенә түгел, ә танылган сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе һәм милләтпәрвәр буларак та яхшы белә.* Р.Вәлиев

**СӘЯСИ** *гар.* **1.** *с.* Сәясәт белән бәйле, сәясәткә караган. *Сәяси җинаятьченең анасына зур шәһәрдә торырга рөхсәт итмәгәннәр.* Н.Сәфәрев. *Якындагы өстәлләр сәяси темага бәхәс-ызгыш кузгатып җибәрде.* З.Фәтхетдинов

**2.** *и. мәгъ.* Политик, сәясәт эшен алып баручы кеше, дипломат. *Сәясәт сәясиләр эше булганга, язган мәкаләләрем җитәр, кабат иҗатка – язасы әйберләремә әйләнеп кайтырмын дигән идем.* Җ.Дәрзаман

**СӘЯСИ-ИКЪТИСАДИ** *с.* Сәяси һәм икътисади характердагы. *Аспирантураны ташлагач та, сәяси-икътисади атамалар сөйләмендә азая төшсә дә, төп ике утраудан торган эчтәлек әллә ни үзгәреш кичерми.* Т.Галиуллин. *XX гасырның башында М.Солтангалиев һәм аның фикердәшләре милли мәсьәләләрне хәл итүнең альтернатив – башка вариантын тәкъдим иттеләр: барлык милләтләр дә сәяси-икътисади белем бирү, мәдәният өлкәсендә бертигез хокукка ия булырга тиешләр.* М.Әхмәтҗанов

**СӘЯСИЛӘШТЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* Берәр нәрсәгә сәяси юнәлеш, рәвеш яки эчтәлек бирү. *Хәзер [«Әлислах»] форматын үзгәртеп, мәсләген дә [юлын, максатын] сәясиләштерергә карар бирдек, бәлки, аннан соң тәртипле бара башлар.* Ф.Әмирхан

**Сәясиләштерә бару** Торган саен ныграк сәясиләштерү

**Сәясиләштерә башлау** Сәясиләштерергә тотыну

**Сәясиләштерә төшү** Беркадәр, беразсәясиләштерү

**Сәясиләштереп бетерү** Бөтенләй, тәмам сәясиләштерү

**СӘЯСИЛӘШҮ** *ф.* Сәяси эчтәлек, юнәлеш, төсмер алу. *Артык сәясиләшү үтерәчәк безнең матбугатны.* С.Зыялы. *Минем фикеремчә, матбугат суытуга караганда күбрәк кыздыра, чөнки ул артык сәясиләштерелгән һәм җаваплылыктан чамадан тыш азат ителгән.* Мәдәни җомга

**Сәясиләшә бару** Беркадәр сәясиләшү

**Сәясиләшә башлау** Сәясиләшергә тотыну

**Сәясиләшеп бетү** Бөтенләй, тулысынча сәясиләшү

**Сәясиләшеп китү** Соңгы арада сәясиләшү. *Госман хәзрәт киткәннән соң, нәзарәт эшчәнлегендә вазгыять кискенләште, дин сәясиләшеп китте, дию белән килешәсезме?* Ватаным Татарстан

**СӘЯСИЛЕК** *и.* Сәяси эчтәлек. *Сәнгатьнең тематик байлыгы да чиксез зур. Шунлыктан һәр сәнгать әсәреннән сәясилек, сыйнфыйлык таләп итеп булмый.* К.Гыйззәтов. *Сәясилек һәм социальлеккә өстенлек бирелү сурәтләү өслүбенең ярлылануына, тараюына китерә.* Ә.Закирҗанов

**СӘЯХӘТ** *и. гар.* Ил гизү, ерак җирләрдә булып дөнья гизү. *Сәяси эзәрлекләүләрдән качып та, ата-бабасының туфрагын зиярәт итәр өчен дә, Камилгә ияреп кайтып, Русия буйлый сәяхәткә чыккан кеше.* Р.Батулла. *Шуңа күрә ата-аналар поход һәм сәяхәтләр, спорт уеннары һәм күңел ачулар оештыру турында кайгыртырга тиешләр.* Йорт эшләре

**СӘЯХӘТ ИТҮ** *ф.* Сәяхәттә йөрү. *Ә бүген ул галәмгә сәяхәт итәргә җыенмый да.* Л.Ихсанова. *Җылы һава кудырып оча торган аэробуста сәяхәт итүләре моңа бер дә ияләшмәгән курчакларга җиңел түгел иде.* Р.Сәгъди. *Бу зур су массасы дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, безнең әйләнә-тирәбездә бик зур механик эшләр башкара, җир өстен һәр көн, һәр сәгать саен үзгәртеп тора.* Дөньяда ниләр бар

**СӘЯХӘТ КЫЛУ** *ф. к.* **сәяхәт итү**

**СӘЯХӘТНАМӘ** *и. гар.-фар.* Юльязма; юлда, сәяхәттә йөрүченең күргәннәрен язган истәлеге, язмасы. *Кулыбызда П.И. Ивановның шул елларда чыгарылган сәяхәтнамәсе.* И.Низамов

**СӘЯХӘТЧЕ** *и.* Сәяхәт итүче, сәяхәттә йөрүче. *Монда ул үзе «леди Лэйлә», аның тирәсендәгеләр – шаһлар, министрлар, атаклы артистлар, сәяхәтчеләр.* М.Маликова. *Сәяхәтчеләрнең язуларына карганда, этләрне ихтирам итеп куелган һәйкәлләр күп икән анда.* А.Шамов

**СБОР** *и. рус* 1) Пионер оешмаларында җыелыш. *Авыр сугыш еллары сәбәпче идеме, тантаналы вәгъдәләр, сборлар, костёрлар аны да, аның иптәшләрен дә читләтеп үтте.* Г.Мөхәммәтшин. *Ни генә эшләсәк тә: мәктәптә пионер сборы уздырабызмы, җилкәгә сәнәк салып иген басуына чыгып китәбезме – без, моны явыз дошманны җиңү сәгатен якынайту өчен дип, чын күңелдән ышана идек.* М.Мәһдиев

2) Кыска сроклы хәрби өйрәнү хезмәте. *Командир мине баштанаяк карап*

*чыкты да: – Иптәш Хикмәтуллин, сез сбордан соң өч көнгә калырсыз, – диде.* М.Әмир. *Кырык беренче елның маенда хәрби сборга алынган вакытта өйдә хатыны, мәктәп яшендәге ике кызы калган.* М.Мәһдиев. *Вуз тәмамлаучылар, армиягә чакырылгач, сборга җибәрелми.* С.Шәрипов

**СБРУЙ** *и. рус к.* **ызбруй**. *Абзар тирәсеннән печән, сбруй, ат тизәге исе, муллык исе бөркелеп тора.* М.Хәсәнов

**СВА́РКА** *и. рус* Эретеп ябыштыру. *Юк, аяк астында ул-бу күренмәде, сварка аппараты янына иелгән Нәгыйм ут көлтәсе чәчрәтеп аңа сәлам бирде.* А.Гыйләҗев. *Сварка җөендә чатнау бар, накладка астына кергән.* Н.Хәсәнов

**СВА́РЩИК** *и. рус* Эретеп ябыштыручы. *Шулвакыт сварщик Кәрим, кулына тоткан электродын швеллерга тукрандай тукылдатып: – Нәрсә, башлыйбызмы әллә? – дип сорап куйды.* Н.Хәсәнов. *Төкерек дигәннән, Рафаэль абый сварщик, ягъни эретеп ябыштыручы булып озак еллар күмхуҗ алачыгында эшләде.* Ф.Яхин

**СВА́СТИКА** *и. санск.* Чатлары туры почмаклап бөгелгән, герман фашизмы эмблемасы буларак таралган тәре сыман билге. *Свастика тәреләре белән Сызып куйдың, Гареб, син аны!* Х.Туфан. *Һәркайсының ян-якларына фашизм эмблемасы – свастика сугылган.* М.Хәсәнов

**СВА́СТИКАЛЫ** *с.* 1) Свастика билгесе төшерелгән. *Күктә свастикалы самолётлар очты, хәрби эшелон Казанга юл тотты.* К.Латыйп. *Фашист свастикалы очкыч бомба яудырмагач, безнекеләр тәмам әтәчләнделәр: аталар да аталар.* Р.Ибраһимов

2) Шундый билге таккан. *Бу кешене, аның фиркасен, мәйданда кара битлек кигән, кулларын нацистлар сәламләвен искә төшерүче свастикалы карагруһлар ят итми торгандыр.* Татар заманы. *Ә XX гасырның иң зур афәтен – фашизмны тар-мар иткән, миллионнарча корбаннар бәрабәренә бөтен Европага азатлык китергән илнең башкаласы Мәскәү урамнарында свастикалы үсмерләр рәхәтләнеп йөри.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**СВЕТОФОР** *и. рус* Яшел, сары һәм кызыл яктылык сигналлары биреп, урамнарда, юлларда тәртипле хәрәкәт саклау өчен куелган электр җайланмасы. *Син светофор сыман тиз үзгәрәсең: бер ярый, бер ярамый...* Ш.Галиев. *Шактый киң урамда, төн уртасы булуга карамастан, машиналар светофор алдында берничә рәткә тезелгән.* Х.Ширмән

**СВИНГ** *и. ингл. икът.* 1) Үзара кредит бирешү. *«Свинг» инглизчәдән «алмашу» дигәнне аңлата.* Татарстан яшьләре

2) *муз.* Джазның бер төре, юнәлеше, стиле. *Шуңа күрә репертуарыбызда рок-музыканың классикасы яңгыраячак: ритм энд блюз, рок-н-ролл, свинг, рок-баллада, фолк, кантри, этника.* Татар заманы

3) *спорт* Бокста ерактан торып янга сугу

4) Парлы бию төре. *«Свинг биегән сыман яшәргә», – дигән язучы В.Аксёнов.* Идел. *Соңгы вакытта Мәскәүдә свинг модага кереп киткән.* Татарстан яшьләре

**СВИ́ТЕР** *и. ингл.* Биек якалы, изүсез, бәйләнгән, төймәләре, каптыргычлары булмаган җылы кофта. *Хәер, кышка таба ул, сары күлмәген салып, свитер киеп йөри иде инде...* М.Мәһдиев. *Бүген халык алдында отчёт ясавын искә алып, кызыл свитер кигән иде [Зәйнәп].* К.Тимбикова

**СВО́ДКА** *и. рус* Агымдагы мәгълүматларны туплап, тәртипкә салып күрсәтә торган белешмә. *Шул хакта авылдан алып үзәк оешмаларга кадәр көндәлек сводка бирелә иде.* Г.Бәширов. *[Әхәт:] Соңгы сводкаларны тыңладыңмы?* А.Гыйләҗев

**СВО́ЛОЧЬ** *и. рус* «Начар, әшәке кеше» дигән мәгънәдә ачуланып, сүгү сүзе. *Кичә дүрт гектар җирне, биш центнерга якын орлыкны харап иткән бит теге сволочь коновал...* М.Әмир. *– Ни сөйлисең син, сволочь!.. – дип кычкырып җибәрде ул, коралы белән кизәнеп.* Г.Әпсәләмов

**СВЯЗНОЙ** *и. рус* 1) Хәрби частьлар, хәрби төркемнәр һ.б. арасында арадашчы, элемтәче. *– Анда майор Ильин ике тапкыр сезне телефонга чакырды инде, – ди связной.* И.Гази. *Тышкы ишектән атылып связной керә.* Ф.Кәрим. *– Немецлар фонарь элгәннәр. Хәзер бомбага тота башлаячаклар, – диде связной, бик гади бер нәрсә турында әйткән кебек.* Г.Әпсәләмов

2) Арадашчы, яшерен рәвештә мәгълүмат тапшыручы. *Син бит, хәшәрәт, алар арасында связной булгансың.* И.Салахов. *Хәмдияне елата-елата сорау алу нәтиҗәсендә, Мөҗипнең чынлап та «связной» булуы ачыкланды.* Х.Ибраһимов

**СД-ПЛЕ́ЕР** *и. ингл.* Компакт дисклар уйнату плееры. *Моннан тыш, тентү вакытында егетнең өендә СД-плеер, ике фотоаппарат, хатын-кыз туннары табылган.* Татарстан яшьләре

**СЕАНС** *и. фр.* 1) Билгеле бер вакыт дәвамында тоташтан, өзмичә күрсәтеләкарала яки башкарыла торган тамаша, күренеш. --- *аларның беренчеме-икенчеме класста укый торган йомшак борынлы малайлары клубта балалар сеансы барганда да, фильмны үзенчә урталай өзеп, өенә торып йөгерә һәм чоланнан кергә-керешли: «Әни, ипи бир!» – дип кычкыра иде.* М.Мәһдиев. *Ничектер шулай килеп чыкты инде: сеанс башланганчы, чирек сәгать фойеда киләп сарып, буталып йөрергә туры килде ---.* А.Тимергалин

2) Берәр эшнең, чараның мәгълүм вакыт дәвамында тоташтан, өзмичә башкарылган өлеше. *Алдан билгеләнгән элемтә сеанслары вакытында да, башка вакытта да алар [космонавтлар] бернинди сигналларга да җавап бирмәс булдылар.* Ч.Айтматов. *Йокыда чакта сабак өйрәтә торган гипноз сеансларын, хәтерне ныгыта торган даруларны әйтмим дә инде.* А.Тимергалин

**СЕБЕР** *и.* 1) Россия Федерациясенең көнчыгышында урнашкан, көнбатышта – Урал таулары, төньякта – Төньяк боз океаны, көньякта – Казакъстан, Монголия, Кытай белән чикләшә торган зур регион. *Бервакыт аңа Себер тайгасында хәрәкәт итүче партизан отрядын табып кайтырга куштылар.* Г.Бәширов. *Себер ягыннан көченеп килгәнгәме икән, бу авыл халкының*

*төс-кыяфәте дә үзенчәлекле: йөзләре саргылт, чәчләре җирәнсу; аларда Чала татарлары чалымы бар.* Р.Батулла

2) Ботаника, зоология кебек фәннәрдәге кайбер тезмә терминнарның ыру яки төрне белдергән компоненты. *Кухнядан, мыраулап, зур йөнтәс койрыклы себер песие килеп чыкты.* А.Гыйләҗев. *Республиканың төньяк районнарында себер карагаен үстерәләр.* И.Рәхимов

◊ **Себер җибәрү** Берәр кешенең тормышын җимерү, нык җәза бирү, олактыру. *Аның инануынча, фидаилар башын Себер җибәргән татар шигыре татлы десерт вазифасын үтәүдән ерак тора.* Ә.Рәшит. **Себер китү** Берәр нәрсә өчен җәза алу, шуның аркасында зур бәхетсезлекләргә юлыгу. *Теге вакытта ак патшаның яхшы күңелле булуына ышанып, сеңлесенең Себер китүенә сәбәпче булуы өчен, ул үзенә ничә еллардан бирле рәнҗи.* Г.Бәширов. *Ул беткән башларга ияреп, ирекле баштан Себер китәр хәлем юк.* Г.Ахунов. **Себер ни – Сембер ни** Барыбер, аерма юк, битараф. *Мин дә сер бирмәдем: – Күрсәм күрермен. Безгә Себер ни – Сембер ни! – дип, артыннан гайрәт күрсәтеп калдым.* М.Гафури. *[Айдар:] Ачу килгән чакта, Себер ни дә безгә, Сембер ни.* Т.Гыйззәт. **Себер сөрү** Себергә сөргенгә җибәрү, сөргенгә сөрү. **---** *кулакларны талап, Себер сөрделәр, шпионнарны атып үтерделәр, муллаларны төрмәдә череттеләр.* М.Кәбиров. **Себер черетү** Озакка тоткынлыкка сөрү, җибәрү. *Тукта! Себер черетәм башыңны! Кулыңа көрәк ал!* М.Кәбиров. **Себер шулпасы чөмерү** Озак еллар сөргендә, тоткынлыкта булу, утырып чыгу. *Чынлап та, үзе белән бергә Себер шулпасын чөмергәннәрдән күпкә бәхетлерәк булып чыкты Гәрдәншакир.* М.Кәбиров

**СЕБЕ́Р БУРСЫГЫ** *и. зоол.* Сусарлар семьялыгыннан кыйммәтле мехлы имезүче ерткыч хайван; коны; *русчасы*: **росомаха**

**СЕБЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **себерү**. *Чәчү өстендә кулны тотарлык булмасын өчен, утынны да күп итеп ярып куйдылар, урамнар, ишегаллары да себерелде.* Г.Бәширов. *Трамвайга утырдылар, төшкәч, чиста итеп себерелгән тын урам буйлап җәяү киттеләр.* М.Маликова. *Ярма-ярма карлар себерелеп торган тымызык кич иде.* Р.Бәшәр

2) *туп.* Теләсә кайда, кайдадыр билгесез яки кирәкмәгән җирләрдә йөрү. *Тарантастан ике ир-ат сикереп төште, аларга башкалар ябырылды: – Эт җаннар, кайда себерелеп йөрисез сез?* М.Маликова. *Казаннан себерелеп кайтканыңа ничә ел, юньле-башлы эш күрсәткәнең юк.* Л.Лерон

3) *туп.* Түбән, бозык тормыш алып бару, ир яки хатын өстеннән йөрү. *Татар байларының марҗалар артыннан себерелгәнен ишеткәнебез бар инде.* Ә.Еники. *Син читтә интегеп йөргәндә, хатының себерелү үрнәкләрен күрсәтте.* Т.Галиуллин

**СЕБЕРКӘЧ** *и. бот.* Төп сабактан чук яки калкан сыман ян тармаклары чыккан катлаулы чәчәк оешмасы. *«Сак атла, – ди капитан. – Дөге кыры бу». Шаккаттым. Шактый юан сабаклы, себеркәч башлы камыш кебек тоелды.* М.Рәфыйков

**СЕБЕРКЕ** *и.* 1) Чүп һәм тузан себерер өчен чыбык яки каты үсемлек сабакчыкларыннан ясалган бәйләм. *Коридор буш. Җыештыручы гына камыш себерксе белән, ачы тузан кузгатып, җилҗил себерә.* А.Гыйләҗев. *Канатның сырты белән дә алдыралмагач, себерке сабы белән кыргычлыйм.* М.Кәбиров

2) Малга кыш ашату өчен җыеп бәйләнә торган яфраклы ботаклар бәйләме; яфрагазык. *Кич кайткач [Тәкый абзый], көрпә болгатып чыгарды, сарай сәндерәсеннән хуш исле юкә себеркесе төшерде. Сыйлансын әйдә [тәкә], сырты сыгылырлык булмасын!* Г.Сабитов. *Каюмнар лапасының салам түбәсен тояклары белән казып, печәнлеккә төшәләр иде дә ут күзләр, хуш ис аңкып торган ямь-яшел себеркеләрне коры чыбыкка калдырып, ишегалды себеркесе ясап чыгалар иде.* Ф.Шәфигуллин

3) Мунчада чабыну өчен юкә, имән, каен һ.б.ш.ның ботакларыннан киселгән яфраклы чыбыклар бәйләме; миллек, мунча яфрагы. *Аннары, ике себерке тотып, мунчага бара [Исхак]: берсе яшь туйрадан бәйләгән себерке булса, икенчесе хуш исле каеннан.* А.Гыйләҗев. *Мунчада себеркесен җайлы гына җилфердәтеп чапкалыйчапкалый: – Әпсен-төпсен, сырхау себеркегә төшсен! – дип сөйләнергә дә иренмәде.* Т.Нәбиуллин

4) *күч. гади с.* Бозык тормыш алып баручы түбән кеше. *[Җиһанша:] Ах, син, урам тастымалы, себерке, хәерче, исән чакта югал күземнән!* К.Тинчурин. *Галимҗан, моңа ирек куймыйча, башын читкә борды. Аннан бик каты итеп әйтте: – Кит моннан, себерке!* С.Поварисов. --- *икенчеләре: «Өстерәлчек, оятсыз, Зөбәрҗәтне әйтәм, ир җитмәгән кебек, Уфасын ташлап кайтып, менә дигән гаиләне боза, себерке», – диләр иде.* Х.Мөдәррисова

**СЕБЕРКЕЛӘ́Ү** *ф.* Себерке итеп бәйләү. *Каен себеркеләү. Мәтрүшкә себеркеләү*

**Себеркеләп бетерү** Барысын да себеркеләү

**Себеркеләп кую** Себерке рәвешенә китереп әзерләү

**Себеркеләп тору** Сөйләү моментында себеркеләү. *Мин килгәндә, әтиең туйра себеркеләп тора иде.* Ватаным Татарстан

**СЕБЕРКЕЛЕК 1.** *с.* Себерке бәйләү өчен дип билгеләнгән, шуңа ярарлык яки җитәрлек булган. *Ботаклары – очта гына [каенның], Бер себеркелек.* Р.Миңнуллин. *Хәтта кайсы елларда бер ишеләре, себеркелек яфрак сындырганың өчен дә, олы-олы штрафлар салып киткәли иделәр.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Себеркегә дигән, шуңа ярарлык яки җитәрлек материал. *Әкрен генә тауга күтәрелдек, тирә-як авылларны күзәттек (безнең таудан Ык буендагы ун авыл күренә), Ачыда җиләк җыйдык, себеркелек алдык.* Татарстан яшьләре

**СЕБЕРТМӘ** *с.* Карны, җир өстендә яткан башка вак нәрсәләрне очыртып, астан гына исә торган (җил, буран тур.). *Мондый себертмә кар-буранлы кыш көнендә Зәкәриянең әле бу кадәр җаваплы эшне беренче башкаруы иде.* Л.Хәмидуллин. *Иптәшкә себертмә буран иярде, йолдызлар күз кысып, көч биреп торды.* З.Кадыйрова

**СЕБЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **себерү** (*1 мәгъ.*). *Дөресрәге, әкәмәтләр буыннан-буынга күчә. Төнлә яшь солдатларның арт якларын каезлап, ант иттерү... Үзе урынына идән себертү, итеген чистарттыру...* С.Шәрипов. *Иң истә калганы: ул безгә идәннәрен себертә, юдырта иде.* Т.Миңнуллин

2) *к.* **себерү** (*2 мәгъ.*). *Көн нык кына салкын. Кар бераз себертә.* Х.Кәрим

**Себертә башлау** Себертергә тотыну. *Йомшак кар яуган көн иде. Әмма төньяктан әз генә җил чыгып тора, кичкә себертә башлавы мөмкин.* М.Шабай

**СЕБЕРҮ** *ф.* 1) Себерке, канат, щётка кебек нәрсә белән сыпырып, әйбернең, урынның өстен чүптән, тузаннан һ.б.дан арындыру. *Киленнең ун яшьлек кызы Зәйнәп кызу-кызу гына идәнне себерде дә каядыр чыгып йөгерде.* Ә.Еники. *Карт-коры, бабайлар абзар-кура тирәсен җыештыра, ишегалды, капка төпләрен себерә.* Г.Галиева

2) Карны, җир өстендә яткан башка нәрсәләрне очыртып, астан гына исү (җил, буран тур.). *Төньяктан зәһәр җил исә, караңгы һәм буп-буш Казан урамнарында җирдән җәяүле буран себерә.* Г.Әпсәләмов. *Җәяүле буран Астан себерә, Аттан да узып Алга йөгерә!* Ш.Галиев. *Кырда салкынча, себерә торган буран.* М.Мәһдиев

3) *з.-сыз* Һава җилле булу; буранлау турында

4) *күч. сөйл.* Бөтенләйгә куып җибәрү, сөрү. *[Батырлар] Дошманны илдән Берен калдырмыйча куган, себергән.* М.Гафури. *Фахиш уенчылар фарс артистларын Англиядән себереп түгәчәк!* Һ.Такташ. *Себер дошманны җир йөзеннән!* Ә.Ерикәй

◊ **Себереп акча эшләү** Күп итеп акча эшләү, каерып эшләү. *Пособие, имеш, ирең Себердә себереп акча эшли, эшләпә белән йөзеккә җитми инде сиңа...* Х.Мөдәррисова. **Себереп алу** Соңгысына кадәр, барысын да бетереп. *Продразвёрстка отрядлары уйлап чыгарып, крестьянны талап, аның соңгы кадагына кадәр себереп алу сәясәтенә күчкән Ленин хакимиятенә каршы Нестор Махно каршы чыга.* З.Зәйнуллин. **Себереп ташлау** Юкка чыгару, бетерү. *Бер яктан, ул вәхши фашистларны кырып бетерү, җир йөзеннән себереп ташлау турында хыяллана.* Казан утлары. **Себереп түгү** Юкка чыгару, бетерү; әһәмиятен, дәрәҗәсен төшерү. *Күр дә тор, себереп түгәчәкбез без аларны!* М.Маликова. *Сәяси һәм социаль тормышыбыздагы җил-давыллар гарасатка әверелеп, әдәбият мәйданындагы сүз осталарын да себереп түкте.* Р.Мирхәйдәров. **Себереп чыгару** Чыгарга мәҗбүр итү; сөрү, куу. *Аны комитеттан себереп чыгардылар.* А.Алиш

**Себерә башлау** Себерергә керешү. *Аннары кулына озын саплы себерке алып, аяк астына җыелган яңгыр суын себерә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Буран себерә башлавы бераз гына борчыды безне, әмма буранда алты чакрым юлга чыгу ул заманнарда проблема идеме соң?* М.Мәһдиев

**Себереп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә себерү. *Тиз генә идәнне себереп алу*

**Себереп бетерү** Барысын да, бөтен җирен себерү, чистарганчы себерү. *Идәнне себереп бетергәннән соң, Кыям, эшләнмәгән тагын нинди эш кала икән дип, бүлмә эчен карап тора башлаган иде, корымга баткан калай чәйнекне күреп аһ итте.* И.Гази

**Себереп кую** Алдан ук себерү; себереп, чиста хәлгә китерү. *Ир-ат, ком белән ышкып, эшлия-камытларның тәңкәләрен ялтырата, дугалар буйый, каеш-йөгәннәрне дегетли, ишегалларын, капка төбендәге яшел чирәмнәрне себереп куя.* Г.Бәширов. *Ишегалдын һәм капка төпләрен күрәп кенә калмады Мирсәет, себереп үк куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**Себереп ташлау** Тиз генә себерү. *Гомеремдә бу тикле эш эшләргә туры килгәне булмаса да, мин болай итәргә уйладым: суны тиз генә алып кайтам да ишегалдын себереп ташлыйм.* В.Нуруллин

**Себереп тору** Сөйләү моментында себерү; гел, әледән-әле себерү. *Буран себереп тора.* М.Мәһдиев. *Дөресрәге, ул салкын иртә җирдән себереп торган җәяүле бураннары белән Майшәкәр апаның хәтеренә үзе ажгырып керә.* Ф.Шәфигуллин

**Себереп чыгару** Башыннан ахырына кадәр себерү. *Кызлар идәнне бик пөхтә итеп себереп чыгардылар.* Ф.Әһлиуллина. *Бармый, гүя аны бакча эчендә коелган яфракларны җыеп, себереп чыгарган зәһәр җил чүп-чар белән бергә очыртып, этеп алып бара иде.* М.Хәсәнов

**Себереп чыгу** Тулысынча, барысын да себерү

**Себереп яту** *сөйл. к.* **себереп тору**. *Икенче тапкыр караганда, Хәйдәр бераз читтәрәк ындыр табагын себереп ята, ул көшел салмакчы була иде шикелле.* Г.Бәширов

**СЕВРЮ́ГА** *и. төрки зоол.* 1) Мәрсин балыклар семьялыгыннан промысел балыгы; укбаш, укборын, орчыкбалык, сөйрек. *Чират Галочкинның үзенә җитә. Аңа да балык уылдыгы, севрюга, бастырма.* М.Юныс

2) Шул балыкның ите; шул балыктан пешереп, кыздырып яки башка ысул белән әзерләнгән ризык. *Аларның өйләрендә дә болай ук булганы юк. Севрюга, грек зәйтүненең җимеше, краблар, уылдыкның кызылы һәм карасы.* Д.Гайнетдинова

**СЕГМЕНТ** *и. лат.* 1) *геом.* Түгәрәктә: дуга һәм аның хордасы белән чикләнгән өлеш, мәйдан; шарда: кисеп үтүче яссылык белән чикләнгән өлеш. *Түгәрәкнең сегменты. Шар сегменты*

2) *зоол.* Кайбер хайваннарның тәнендәге охшаш өлешләрнең берсе яки аерым бер органы. *Сөлек тәненең тышкы боҗралары һәм эчке сегментлары саны бертигез түгел. Якынча 3–5 тышкы боҗрага бер эчке сегмент туры килә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Күптөкләләргә тәненең ян-ягында сегмент саен урнашкан кыска мускуллы хәрәкәтчән үсентеләр – пар параподияләр булу хас.* Биология

3) Нәрсәнең дә булса бер өлеше. *Сабактагы яфраклары утырма, яфрак җәймәсе кыяклы сегментларга бүленгән, алар, нигезләре белән кушылып, чәчәк астында касәгә охшаш кыңгыраусыман җиңсә барлыкка китерә.* Ботаника

4) *лингв.* Катлаулы тел берәмлегенең бер өлеше (мәс., фонема, морфема –

сүзне тәшкил итә торган берәмлекләр). *Авазлар – телнең сегмент элементлары, басым һәм интонация – суперсегмент элементлар.* Ф.Сафиуллина

**СЕГМЕНТЛАНУ** *ф.* Сегментларга бүленү

**СЕГРЕГА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Расага карап дискриминацияләүнең бер төре: милләт яки тән төсе нигезендә хокукларны чикләү

**СЕЗ** *а.* 1) II зат алмашлыгының күплек формасы. *Сез төзисез, сез өмет белән яшисез.* Т.Миңнуллин

2) Берәүгә, гадәттә, җитәкчеләргә, олы кешеләргә яки чит кешегә турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә ихтирам йөзеннән кулланыла. *Сез кем, нишләп йөрисез монда?* Ф.Яруллин. *Чөнки Сез киң җәмәгатьчелеккә күбрәк сәясәтче, дәүләт эшлеклесе буларак билгеле.* Р.Вәлиев

**СЕЗОН** *и. лат.* 1) Елның аерым бер климатик билгеләр белән характерлана торган вакыты; фасыл. *Ул елларда литфонд вәкиле Сәмитов җәйге сезон өчен язучыларга Түбән Ослан авылыннан дачалар ала торган иде.* Г.Бәширов. *Чөнки кыш бетмәгән әле, яз җитмәгән дигәндәй, агайның өс-башы сезонга туры килми иде, шуның өстенә киемсалымы артык алама иде.* Р.Зарипов

2) Елның берәр эш өчен уңайлы булган чагы; билгеле бер эш башкарыла торган вакыт. *Мәсәлән, балык сезоны бик кызган айларда валерьянка табу кыенлашып киткән чаклар була.* М.Әмир. *Сезон башланырга да күп калмады. Нинди чимал белән, ничек итеп асфальт чыгарырлар?* З.Дәүләтов

3) Ике җәйге ял арасында концерт яки спектакльләр куела торган вакыт. *Ниһаять, сезон ачылып, спектакльләрнең берсенә баргач, мин театр бинасында Нәгыймә апа Таҗдарованы очраттым.* Ә.Еники. *1915/16 ел сезонында «Сәйяр» шактый зур кыенлыклар кичерә.* Г.Арсланов

**СЕЗОНЛЫ** *с.* 1) Елның билгеле бер вакытында, бер сезонда гына була торган. *Ул менә ничәнче кабат инде, әллә кала тирәләренә сугылып, берәр сезонлы эшкә ялланып карыйммы икән, дигән нияте барлыгын әйтте.* М.Хәсәнов. *Ул Урта Азиядәге абыйсы янына акча күп төшә торган сезонлы эштә эшләп йөрде, армиядән соң Себердә урман кисте.* Р.Кәрами

2) Билгеле бер сезонда вакытлы эш башкаручы. *Моңа кадәр тракторчылар, бригадирлар һәм комбайнчылар МТСларда сезонлы эшчеләр булып кына исәпләнделәр.* Т.Гыйззәт. *Бу – Рәхим Нуруллин, карт шахтёр, сезонлы эшче.* Һ.Такташ

3) Аерым бер сезон өчен генә билгеләнгән. *Әдәбият ләкин сезонлы азык кына түгел, әйтик, быелгы яңа җиләк, быелгы яңа кыяр, быелгы суган гына түгел бит ул.* Х.Туфан

**СЕЗОНЛЫЛЫК** *и.* 1) Сезонлы (*1 мәгъ.*) булу. *Безнең республикада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә сезонлылык түбәндәгечә билгеләнә: җәйге сезон – 16 май – 31 август; көзге сезон – 1 сентябрь – 15 ноябрь; кышкы сезон – 16 ноябрь – 15 март; язгы сезон – 16 март – 15 май.* Товар турында мәгълүмат укыйбыз

2) Сезонлап эшләү-эшләтү тәртибе. *Безнең эшкә сезонлылык хас инде, нишләтәсең.* М.Әмир. *Хәзер юллар төзү эшендә сезонлылык бетерелде.* М.Хәсәнов

**СЕЗО́ННИК** *и. рус сөйл.* Сезонлы эшче. *Укыта торган җирем сезонниклар яшәгән озын баракның кызыл почмагында...* Ә.Еники. *Төрле авыллардан җыелып, сезонник булып ялланган балта осталары, такта яручылар артеле өч-дүрт ай эчендә, бер рәткә тезеп, контора йорты, кадровый эшчеләр өчен куш буралы җиде барак җиткереп куйды.* Т.Мөбарәков

**СЕЙВАЛ** *и. ингл. зоол.* Буй-буй китлар семьялыгыннан кысласыманнар һәм балыклар белән туклана торган эре кит

**СЕЙЛ** *и. ингл.* Бәйрәм уңаеннан яисә сезон ахырында товарларны түбән бәядән сату

**СЕЙМ** *и. пол.* 1) Польша, Финляндия, Латвия, Литвада парламент. --- *1917 елның мартында Финляндиянең элек тыелган Конституциясе гамәлгә керә, 18 июльдә исә Сейм Финляндия автономиясе хокуклары турында закон кабул итә, әмма Вакытлы хөкүмәт бу законны юкка чыгара, Сейм таратыла.* Г.Исхакый. *Аның ярдәме белән икенче көнне радио-телевидение аша интервью бирәм, Татарстан турында сөйлим, [Латвиянең] Сейм депутатлары белән очрашам.* З.Зәйнуллин

2) Көнчыгыш Европаның кайбер элекке феодаль дәүләтләрендә сословиечел вәкиллекле орган

**СЕ́ЙНЕР** *и. ингл.* Балык аулый торган кечкенә диңгез судносы. *Узган ел ул Сахалин сейнерында машинист булып эшләгән иде.* Ф.Шәфигуллин. *Җимерек трюмдагы балык һәм ятьмәләр, сейнер бата барган саен, өскә калкып чыга торалар, салмак кына тибрәнгән дулкыннар аларны төрле якка тараталар иде.* С.Сабиров

**СЕ́ЙСМИК** *с. махс.* Җир тетрәү күренешләренә мөнәсәбәтле. *Көлмәгез, көлмә, Татарстанда сейсмик станция төзергә күптән вакыт.* Р.Зәйдулла. *Ә менә сейсмик прибор үзен сәеррәк тотты.* Ш.Бикчуров. *Моннан биш-алты ел элек Россия Фәннәр академиясенең җир физикасы институты илнең яңа сейсмик картасын төзеде.* Шәһри Казан

**СЕЙСМО́ГРАФ** *и. гр.* 1) Тетрәү һәм шартлаулар вакытында җир кабыгының тирбәнүен язып бара торган прибор

2) *күч.* Барысын да сизеп, белеп һәм аңлап торучы, аны чагылдыручы. *Газетаны җәмәгатьчелек сейсмографы дип атарга була.* Г.Бәширов. --- *катып калган формалар түгел, ул – үзе чагылдырган чынбарлыкның тәэсире астында үзе үзгәрә торган гадәттән тыш сыгылмалы организм, ул – бөтен нәрсәне сизә торган, җир астындагы теләсә нинди үзгәрешләрне теркәүче сизгер сейсмограф.* И.Илялова

**СЕЙСМОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Җир кабыгының тирбәнүен язу

2) *к.* **сейсмология.** *Эрегән магма моннан ерак түгел, электромагнит һәм сейсмография разведкалары күрсәткәнгә караганда якынрак ята иде күрәсең.* А.Толстой

**СЕЙСМОДУЛКЫН** *и.* Җир тетрәүдән, зур шартлаудан таралган тирбәнүләр

**СЕЙСМО́ЛОГ** *и. гр.* Сейсмология белгечe. *Вадим Зуфирәне башка кунаклар белән таныштырды: икесе дә озын буйлы, туры сынлы, ыспай киемле ир белән хатын, берсе – геолог, икенчесе сейсмолог икән.* М.Маликова

**СЕЙСМОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Җир тетрәүләрне, шартлауларны өйрәнә торган фән тармагы. *Мәгълүм булганча, СССР хөкүмәте күптән түгел, Фәннәр академиясе каршындагы сейсмология буенча эксперт комиссиясе нәтиҗәсенә таянып, Татарстан АЭСын тиз арада сафка кертелергә тиешле корылма сыйфатында финанслау турында карар кабул итте.* Ә.Сәлах. *Менә шуңа күрә дә галимнәр Казанда сейсмология хезмәте булдыру тәкъдиме белән чыктылар.* Татарстан яшьләре

**СЕЙФ** *и. ингл.* Акча, документ һ.б. кыйммәтле нәрсәләр саклау өчен янмый торган корыч шкаф, тартма яки махсус бүлмә. *Зәңгәр кнопкага баскач, сейфның авыр тимер ишеге әкияттәге сихри капка кебек әкрен генә ачылып китте.* А.Тимергалин. *Ул урыныннан торып почмактагы сейфка юнәлде.* Г.Сабитов

**СЕЙШН** *и. ингл.* Кечкенә клубта яки фатирда үткәрелә торган концерт-тамаша; музыкаль кичә. *Монда картиналар күргәзмәсе, Удмуртия Рәссамнар берлегеннән киләчәк дусларыбыз (Юрий Лобанов, Александр Пушин) катнашында видео-арт, музыкаль сейшн («Барадж» төркеме), перформанслар (Александр Бусыгин, Альберт Шиһабиев һ.б.) булачак.* Шәһри Казан

**СЕ́КАНС** *и. лат. мат.* Турыпочмаклы өчпочмакта гипотенузаның әлеге почмакка чиктәш катетка чагыштырмасына тигез булган тригонометрик функция

**СЕКА́ТОР** *и. фр.* Агач һәм куакларның калын булмаган ботакларын кискәндә һ.б. бакча эшләрендә кулланыла торган махсус кайчы; бакча кайчысы. *Ул арада, көрәк, тырма, секатор ише коралларын күтәреп, берничә кыз керә.* Ф.Яруллин. *Әгәр аларда кышлаган бөҗәкләр, аларның йомыркалары бар икән, бу ботакчыкларны секатор белән кисеп атарга кирәк.* Шәһри Казан

**СЕКВЕСТР** *и. лат.* 1) *махс.* Берәр төрле милектән файдалануны өлешчә яки тулысынча тыю (хакимият органнары тарафыннан эшләнә). *Йортҗиргә секвестр салу. Банктагы счётка секвестр салыну*

2) *мед.* Берәр төр тукыманың, гадәттә сөякнең, үлеп, сау тукыма эчендә урнашкан өлеше, кисәге. *Сөяк секвестры*

**СЕКВО́ЙЯ** *и. лат. бот.* Кипарисчалар семьялыгыннан кайберләренең биеклеге 100 метрга, яше 2500 гә җиткән, Төньяк Америкада үсә торган мәңгеяшел ылыслы агач. *Секвойя, нарат кебек гигантлар турында һәркем белә.* Биология. *Алар арасында уникаль булганнары да шактый: мәһабәт секвойя урманнары, гаять зур күлләр, ләм вулканнары һәм гейзерлар өлкәләре, тирән елга үзәнлекләре – каньоннар һ.б.* Материклар һәм океаннар географиясе

**СЕКОНД-ХЕНД** *и. ингл.* Кулланууда булган, тотылган әйбер һәм шулар белән сату итә торган кибет. *Киемнәре бик килешле, бер дә «Секонд-хенд» кибетеннән димәссең.* Сөембикә. *АКШта һәм Европада яшәүчеләр «Секонд-хенд» дигәндә акча янчыкларын ачып салырга әзерләр, имеш.* Шәһри Казан

**СЕКРЕТ** I *и. лат. хәрби* Яшерен күзәтү посты һәм шул постта торучылар төркеме. *Як-якларга секретлар куеп чыккач, [командир] партизаннарны үз янына чакырды.* И.Туктар. *Сугышчыларның күпчелеге йоклый. Тик часовойлар, алдагы дозорлар, секретлар гына төннәрне йокысыз үткәрәләр.* Г.Иделле

**СЕКРЕТ** II *и. лат. физиол.* Биз сыекчасы. *Нектарны эшкәрткәндә, бал кортлары аңа составында инвертаза ферменты булган йоткылык бизе секреты өстиләр.* Татар балы. *Гөберле баканың тиресе бүлеп чыгарган секрет күзгә һәм тиредәге тырналган урыннарга эләккәндә, аз гына пешергәндәй була.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**СЕКРЕТАРИАТ** *и. фр.* 1) Дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында гомуми оештыру һәм җитәкчелек яки секретарьлык эшләрен үтәүче бүлек, орган. *Яхшы ук грамоталы, зиһенле егет, үсәүсә, ахырда Башкортстан Үзәк Башкарма Комитеты секретариатының мөдире, аннары Совнарком каршындагы дини эшләр идарәсенең җитәкчесе булуга чаклы барып җитә.* Ә.Еники. *Шуннан соң мине секретариатка чакырдылар.* С.Ибраһимова

2) Төрле оешмаларның агымдагы язу-язышу эшләрен алып бара, секретарьлык вазифаларын үти торган бүлеге. *Редакцияләп, секретариатка тапшырдым.* Г.Әпсәләмов. *«Карале, – диде Җәвад абый, – синең өчен тулы бер секретариат эшли диләр, дөресме?»* Ф.Яруллин

3) *җый.* Шундый бүлектә, урында эшләүчеләр. *Секретариат исемлеге*

**СЕКРЕТАРЬ** I *и. лат.* 1) Дәүләт яки җәмәгать оешмасының яисә аерым кешенең гомуми язу-сызу, кәгазь эшләрен башкаручы. *Яхшы, алайса, Уразаева, секретарьдан академик отпуск алуыгыз турында кәгазь тутырыгыз, миңа китерегез, кул куярмын...* Г.Ахунов. *Башта, факультет секретаре бу хәбәрне әйтүгә, пыр тузып ачуландым.* И.Салахов. *Шулай дип, Миңлевәлиев секретарь бүлмәсенә чыкты.* Р.Сәлим

2) Җыелыш-утырышларда беркетмә язучы. *Секретарь бик озын итеп протокол язды.* М.Әмир. *Җыелышның председателе мин үзем булырмын. Протокол язарга секретарь кирәк.* Г.Мөхәммәтшин

3) Нинди дә булса сәяси төркемнең сайлап куелган җитәкчесе. *Курт бүген көндезге унберда районнардан килгән колхоз партоешмасы секретарьлары белән очрашырга тиеш икән.* А.Гыйләҗев. *Г.И. Усманов Мәскәүгә киткәч, беренче секретарь урынына пленумда сезнең кандидатураны да тәкъдим иттеләр.* Р.Миңнуллин. *Беренче секретарьга керәсе иде.* В.Нуруллин

**СЕКРЕТАРЬ** II *и. лат. зоол.* Лачын кошлар семьялыгыннан Африкада яшәүче, озын аяклы һәм башында каз каурыйларына охшаш, төрле якларга тырпаеп тора торган бүреге булган ерткыч кош

**СЕКРЕТАРЬЛЫК** *и.* Секретарь вазифасы һәм эше. *[Сәлах:] Иптәш Баязитов, Лотфый секретарьлык эшләрен тапшырмый торсын иде әле.*

Т.Гыйззәт. *Секретарьлыкка сайланганнан соң, егетләрнең икенче төрлерәк карый башлаганнары сизелде.* М.Юныс. *Хәер, ул вакыйгадан соң бер атна үттеме-юкмы, аны секретарьлык эшеннән азат иттеләр.* М.Мәһдиев

**СЕКРЕТЕР** *и. фр.* Шкафның язусызу өчен махсус кайтармалы яки шудырып чыгарыла торган тактасы һәм кәгазьләр саклау өчен тартмалары яисә шүрлекләре булган бер төре. *Секретер өстендәге журналларга якты ут сибелде, яшел ут исә минем арттагы стена эченә кереп качты ---.* Г.Госман. *Икенче якта секретер, янәшәсендә диван-карават.* М.Маликова

**СЕКРЕ́ЦИЯ** *и. лат. физиол.* Биз күзәнәкләрендә махсус сыекча эшләнү һәм бүленеп чыгу күренеше. *Эчке секреция бизләре бүлеп чыгара торган гормоннар исә, гомумән, могҗизага тиң: алар организмның бөтен тереклек эшчәнлегенә тәэсир итәләр.* Ф.Бәйрәмова. *Эчке секреция бизләре, үт куыгы, эчәклек, бәвел юлларына операция ясату тыела.* Мәдәни җомга. *Аның нигезендә эчке секреция бизләре эшләп чыгарган, үзенә бертөрле актив химик матдәләр – гормоннарның тәэсире ята.* Биология

**СЕКС** *и. лат.* Җенси мөнәсәбәтләргә караган һәрнәрсә. *Ул секс дигән нәрсә адәм баласы тормышында зур роль уйный шул.* А.Хәсәнов. *Бөтенесен заман юньсез якка борды – «Секс» сүзе «мәхәббәт»не алыштырды: Гыйффәтлеләр Чибәркәйләр табынында Ни өчендер хәзер артык кашык булды.* Ә.Рәшит. *Ә секс (эчке секреция бизләре эшен һәм гормоннар эшләп чыгаруны көчәйтә) – яшәрүнең, димәк, озын гомерле булуның менә дигән чарасы!* Ватаным Татарстан

**СЕКСАЗЧЫЛЫК** *и.* Җенси мөнәсәбәтләргә кагылышлы нормалардан тайпылган кешеләр

**СЕКС-БО́МБА** *и. ингл.* Көчле тәләк, шәһвәт, дәрт уята торган, сексуаль хатын-кыз. *Әллә гәҗитләрдә секс-бомба дип яза торган хатын-кызлар Мөслимә төслеме икән?* Н.Әхмәдиев. *Шуңа өстәп, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, Килдебәковның кызы – секс-бомба, дигән сүз дә таралса?* Р.Зәйдулла

**СЕКСИЗМ** *и. ингл.* Җенес нигезендә дискриминация; бер җенесне икенче җенестән өстенрәк санау (аеруча хатын-кызларга карата). *Сексизм һәм физиологик инстинктлар артистларда күренеп тора.* Шәһри Казан

**СЕКСО́ЛОГ** *и. лат.-гр.* Сексология белгече. *«Мин – сексолог!» – дип, түш киереп, масаеп йөрүчеләр бар.* М.Маликова. – *Пассажирлар белән психолог та, сексолог та, юрист та булып бетәсең, – диде танышым, ярым шаяртып.* Ватаным Татарстан

**СЕКСОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Җенси мөнәсәбәт, гаилә, җенси тәрбия мәсьәләләрен медицина, физиология, психология белән бер яссылыкта өйрәнә торган фән. *Алай гына да түгел, соңгы вакытта балаларда табигый инстинктны кечкенәдән уяту өчен, хәтта мәктәпләрдә «Сексология» дигән яңа фән дә кертмәкчеләр.* Татарстан яшьләре

**СЕКСОПАТОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Җенси тормыш, җенси мөнәсәбәтләргә кагылышлы тайпылышларны яки авыруларны өйрәнү һәм дәвалау белән шөгыльләнә торган медицина тармагы

**СЕКСОТЕРАПИ́Я** *и. лат.-гр.* Ир белән хатын, гомумән, җенси мөнәсәбәттәге парлар арасындагы сексуаль характердагы проблемаларны, дисгармонияне бетерү, аларны терапия һәм психотерапия алымнары ярдәмендә дәвалау

**СЕ́КСТА** *и. лат. муз.* Алты баскыч киңлегендәге музыкаль интервал

**СЕКСТАНТ** *и. лат. махс.* Астрономик һәм геодезик күзәтүләр өчен почмак үлчәү коралы. *Кулына секстант тотып, өске палубага менү белән, әлеге гади штурман җиденче кат күкнең серен белүче фәрештәгә әйләнә.* М.Юныс. *Йолдызчылар квадрант, секстант кебек җайланмалардан киң файдаланганнар.* Татар милли педагогикасы

**СЕКСТЕТ** *и. ит. муз.* 1) Алты тавыш яки алты уен коралы өчен язылган әсәр

2) Алты башкаручыдан (җырчы яки уен коралында уйнаучыдан) төзелгән ансамбль, төркем. *Анда Ташкентның иң әйбәт джаз секстеты уйный, тагын да төгәлрәге, негр шикелле каракучкыл йөзле, озын гәүдәле үзбәк егете – саксофончы Хәлил сихерле иде аның күңелен.* Р.Мирхәйдәров. *Туй мәҗлесендә, өч парның (--- бу ансамбльне мин хәзер «секстет» дип атар идем) әлеге җырны бергәләп башкаруы кунакларны шаккатырды.* К.Шакиров

**СЕКСТИЛЛИОН** *и. фр.* Бер цифры һәм егерме бер ноль белән күрсәтелә торган сан. *Әйтик, унбиш нольдән торган санны квадриллион, унсигез нольдән торганын квинтиллион, егерме бер нольлесен секстиллион, егерме дүрт нольлесен септиллион, егерме җиде нольлесен октиллион дип атыйлар.* Татарстан яшьләре

**СЕКСУАЛИЗМ** *и. кит.* Җенси тойгыга һәм хискә бирелүчәнлек

**СЕКСУАЛЬ** *с. кит.* Җенси тойгыга яки якынлыкка мөнәсәбәтле, шуңа караган. *«Һәр сексуаль хискә ирек бир дә Яшәп кал син әйдә, янәсе, Дөньяны бит барыбер юк итәчәк Термоядер сугыш ядрәсе».* Х.Туфан. *Тик хатын-кызга мин беркайчан да сексуаль яктан гына карамадым.* Т.Миңнуллин

**СЕКС-ШОП** *и. ингл.* Сексуаль, эротик характердагы товарлар белән сату итә торган кибет. *Ә ул, тере хатын булмыйча, секс-шоп кибетләрендә сатыла торган резин курчак – җенси курчак икән.* Мәдәни җомга. *7 ноябрьдә Русиядә мөселманнар өчен хәләл интим товарлар (ягъни хәләл секс-шоп) сатучы интернет-кибет ачылды.* Татарстан яшьләре

**СЕ́КТА** *и. лат.* 1) Хакимлек иткән диннән аерылып чыккан, дини догмалары һәм йолалары үзгәрәк булган төркем яки җәмәгать. *Баксаң, урыс миссионерларының кайсыдыр сектасы (православиедә 3500 төрле секта барлыгын беләм) татарларны үз диннәренә кыстау максаты белән чыгарган чираттагы тиражы икән.* Ф.Баттал. *Әлеге уңай җирлекне тоемлаган дини сектала р – кришнаитлар, баһаилар, евангелист-баптистлар, протестант-харизматиклар һ.б. – яшьләр арасында колачлы миссионерлык эшләре алып бара башладылар.* Ш.Җәләлиев

2) *күч.* Күпчелек халыктан аерылып, үзләренең вак, тар ихтыяж-максатлары даирәсе белән чикләнгән кешеләр төркеме. *Ялангач су коену ул әле секта*

*дигән сүз түгел.* Ватаным Татарстан. *Сәяси партия ул – клуб, секта түгел, ул 100 кешегә генә юнәлдерелгән җәмгыять түгел.* Безнең гәҗит

**СЕКТАНТ** *и. лат.* 1) Берәр дини секта әгъзасы. *Сектантлар безнең Татарстанда бөтенләй юк та бугай бит әле.* Г.Тавлин. *Әлеге чорда вәисиләр турында мәгълүматыбыз бик ярлы булды, чөнки аларга «сектантлар», «Совет хакимияте дошманнары» дигән ярлыклар тагып өлгергәннәр иде инде.* Р.Вәлиев. *Шул ук Интернет порнография һәм сектант сайтлары белән тулган.* Ватаным Татарстан

2) *күч. кит.* Халыктан аерылып, үзенең вак, тар ихтыяҗ-максатлары белән чикләнгән кеше (җәмәгать эшлеклесе һ.б.ш.)

**СЕКТАНТЛЫК** *и.* 1) Сектант (*1 мәгъ.*) булу хәле. *Аны киң массага авыр аңлаешлы дини терминнардан, төрле кабатлаулардан арындырганда, сектантлыкның чын асылын һәм зарарын ачыклыйрак төшкәндә, һичшиксез бастырырлык иде.* Г.Тавлин

2) *күч.* Күпчелектән аерылып, вак, тар ихтыяҗ һәм максатлар белән чикләнү күренеше

**СЕ́КТОР** *и. лат.* 1) *мат.* Яссылыкта түгәрәкнең ике радиус һәм дуга белән чикләнгән өлеше. *Түгәрәк секторы*

2) Берәр мәйданның радиаль сызыклар белән чикләнгән өлеше. *Менә астан, Идрисләр секторының сул ягыннан, кардай ак майкалар, саргылт трусиклар кигән таза-таза җирән егетләр җитез генә [футбол кырына] йөгерешеп чыкты.* А.Гыйләҗев

3) Дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында бүлек, бүлекчә. *Минемчә, сектор үзе өчен кимендә тагы ике художник булдырырга тиеш.* А.Алиш. *Чөнки ул берәр гыйльми оешмада, югары уку йортында штатта тора, галимнәргә бирелә торган кандидат, доктор дәрәҗәсен йөртә, доцент, профессор, сектор мөдире, кафедра мөдире, директор, ректор дигән хезмәт урыннарының берсен били.* М.Мәһдиев

4) Дәүләт эшенең, халык хуҗалыгының берәр тармагы, өлкәсе. *Үз өйләре, каралты-куралары белән яшәгән шәхси секторда эт-маэмай заты һәр йортта бар.* А.Хәсәнов. *Дәреслек өлкәсендә (чагыштырмача төшемле секторда) кәсеп итү максатын куйган нәшриятлар, төрле алымнар кулланып, Русия кибетләрендә сатып алучыларны «аулыйлар».* М.Вәлиев

**СЕКУНД** *и. лат.* 1) Минутның алтмыштан бер өлешенә тигез вакыт үлчәү берәмлеге; дәкыйка. *Биш минут түгел, биш секунд та торалмыйм, уттай эш өсте икәнен беләсез, дип, выжылдап кына узып китте.* В.Нуруллин. *Секунд эчендә никадәр уй Мотаһирның башында...* Р.Кәрами

2) Бик кыска гына вакыт; бер тын; бер мизгел. *Маһибәдәрнең бер минут та, бер секунд та яшисе килми, чөнки алдагы көннәренең мәгънәсе, кирәклеге күренми иде.* А.Гыйләҗев. *Шул секундта Галимҗан сул якта басып торган яшь ханымга игътибар итте.* С.Поварисов

3) *мат.* Градусның 1/3600 енә тигез булган почмак яки дуга үлчәү берәмлеге. *Ул, нәкъ Таймас көткәнчә, илле биш градус булып чыкты да. Монда инде плюс-минус секундларның әһәмияте юк.* А.Тимергалин

**СЕКУНДАНТ** *и. лат.* 1) Дуэльгә чыгучының арадашлык һәм шаһитлык хезмәтләрен үтәүче ышанычлы кешесе. *Тик дуэльләр генә хәзер Элеккечә түгелләр. Атыш юк, секундантлар юк, Хәбәр итү юк алдан: Белмисең кай җирдә сине Сагалый мәкер, ялган.* Ф.Яруллин. *Мин язмышка дуэль тәкъдим итәм, Секундантым минем булырсың.* Ф.Гыйльфан

2) Бокс, шахмат, фехтование һ.б.ш. ярышларда катнашучылардан берсенең арадашчысы һәм ярдәмчесе. *Икенче ояты: Гатаның [Г.Камский] көндәше Анандның секунданты булып икенче бер татар баласы – Артур Юсупов ялланган.* Т.Миңнуллин

3) Шаһит, күзәтүче, арадашчы. *Секундантыгыз була алам.* Т.Гыйззәт. *Ярыш, билгеле, Шәрәф белән икебезнең арада бара. Кызлар – секундант.* Л.Ихсанова

**СЕКУНДАНТЛЫК** *и.* Секундант вазифасы

**СЕКУНДЛАП** *рәв.* 1) Бер секунд чамасы (вакыт тур.)

2) Һәр секунд саен; секундлар үткән саен. *Әнә шулай, секундлап, минутлап кына булса да, һаман уза тормыш.* Г.Бәширов. *Олы бәхет тә бары берьюлы тау булып килеп төшми бит ул. Минутлап, секундлап җыела.* К.Тимбикова

3) Секундлар белән санап (вакытны исәпләү тур.). *Әлбәттә, мәсьәләне чыгарган чакта, бензинны – граммлап, юлны – метрлап, вакытны секундлап санап тормыйсың, һәммәсен дә түгәрәкләп исәплисең инде.* С.Баттал. *Минем вакыт, кайберәүләрнеке кебек, алай секундлап үлчәнми.* Г.Әпсәләмов

**СЕКУНДЛЫ** *с.* Секундлар белән исәпләнә торган; бик аз (кыска вакыт арасы тур.). *Тик Россия күләмендә бу эш тулысынча төгәлләнми торып, секундлы тарификациягә күчеп булмаячак әле.* Ватаным Татарстан

**СЕКУНДЛЫК** *с.* 1) Бер секунд дәвам итә торган. *Секундлык каушау моментында үзеңне кулга ала алмасаң – беттем диген.* М.Мәһдиев. *Дөнья агышында секундлык балку булып, безнең гомерләр дә ялтырап ала...* Татарстан яшьләре

2) Секундлар белән генә үлчәрдәй әз һәм бик кыска вакыт эчендә, тиз генә башкарыла торган. *Хәтта, берничә копия алып, аларны яшерен урында сакларга була, кирәксә, аларны юкка чыгару – секундлык эш, клавишага гына басасы.* Р.Мирхәйдәров. *Аннан соң, сыйныфтагы барлык укучыларның бөтен билгесе күз алдында тезелеп тора бит, ә кәгазь журнал битен ачып карау – секундлык эш.* Татарстан яшьләре

3) Секундларны күрсәтә торган (сәгать угы). *Секундлык, минутлык, сәгатьлек уклар бердәм булганда гына, вакытны дөрес күрсәтәләр.* Ш.Галиев

4) *күч.* Бик кыска мизгелле. *Дөнья агышында секундлык балку булып безнең гомерләр дә ялтырап ала...* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Узгынчы, тиз үтә, бетә торган, әһәмиятсез. *Бер мәртәбә салют биреп, секундлык кызык өчен акчаны төтенгә әйләндергәнче, шундыйларга ярдәм итеп күчерсәләр...* Туган як

**СЕКУНДОМЕР** *и. рус* Вакытны секундның унарлы өлешенә кадәр төгәллек белән үлчи торган әсбап. *Кече габаритлы радиометрны, дулкын үлчәгечне, секундомер кебек нәрсәләрне ул сакланып кына өстәл читенә алып куйды һәм кәгазьләрне күздән кичерә башлады.* А.Тимергалин. *Шул мизгелдә, секундомер төймәсенә басып, вакыт билгеләде.* Р.Ибраһимов

**СЕ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Дәүләт оешмалары һ.б.ш.ларда бүлек яки бүлекчә. *Сәүдә министрлыгы белән берлектә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә икетеллелекнең тормышка ашырылуы мәсьәләләре буенча махсус секция эшләячәк.* Р.Миңнуллин

2) Съезд, конгресс, конференция, киңәшмә һ.б.ш.ларда катнашучыларның бертөрле мәсьәләләрне тикшерү өчен төзелгән төркемнәрдән берсе. *Дормидонтов табигать саклау җәмгыятенең фән секциясенә җитәкчелек иткәнлектән, Камилнең аңа берничә мәртәбә йомышы төшкәне бар.* Г.Бәширов. *Җыелышта булсын, мәҗлестә, идарә яисә секция утырышларында, очрашуларда булсын, ни дә булса язылa, өр-яңа фикерләр теркәлә.* Р.Миңнуллин

3) Нинди дә булса спорт, сәнгать берләшмәсенең структурасындагы билгеле бер юнәлештә эш алып барган бүлекчәсе. *Беренче, икенче курсларда ул [Ләйлә], баскетбол секциясенә йөреп, университет командасы составында ярышларга да катнашты.* А.Гыйләҗев. *Мәктәптәге яшь педагогларның берсе булган Илнурның дзюдо буенча беренче разрядлы спортчы икәнлеген белгәч, аңа укучылар өчен секция ачарга тәкъдим ясады.* Ф.Зариф

4) *махс.* Каралты-корылма, эре җиһаз кебек нәрсәнең өлеше, ваграк бүлемтекләрдән торган буыны, кисәге, блогы, торыгы. *Маш җиде секциядән тора, һәм аны җиде баскычлы дип йөртәләр иде.* М.Мәһдиев. *Ишекне ачып кергәч, Илфат тәрәзә астына куелган батареяга төртеп күрсәтте: – Ничә секция булырга тиеш монда, инженер?* Р.Вәлиев

**СЕКЬЮ́РИТИ** *и. ингл.* 1) Куркынычсызлык хезмәте

2) Сакчы; каравылчы. *Безне секьюрити елмаеп озатып калды.* Ватаным Татарстан. *Этикеткасын укырга яки, кирәк дип тапсагыз, «менеджер» дип аталган кибетчеләрен, «секьюрити» дип аталган каравылчыларын чакыртып, хокукларыгызны дауларга мөмкин.* Безнең гәҗит

**СЕЛӘГӘЙ** *и.* 1) Авыз куышлыгында бүленеп чыга һәм азыкны юешләпчылатып эшкәртү өчен хезмәт итә торган сыекча, сузылучан төкерек. *Авызыннан асылынып төшкән селәгәй тасмасы белән бергә аның күңеле дә җиргә тама иде төсле.* Р.Зәйдулла. *Авылда яки шәһәрдә яшәүче карлыгачлар ояларын, балчык кисәкләрен җилемле селәгәйләре белән ябыштырып, өй кыекларында, тәрәзә өсләрендә коралар.* Кошлар

2) *күч.* Булдыксыз, җебегән, ихтыярсыз кешегә карата әйтелә. *Бер-ике селәгәй шуңа сатылып, ялманып йөри!* А.Гыйләҗев. *Рәис өстәлгә шап итеп сукты: – Селәгәйләр! Аны саграк эшләп булмый идемени?!* Ф.Яруллин

◊ **Селәгәй авыз** Җебегән, булдыксыз, оешмаган кеше; мәми авыз. *Хәдис, каушавыннан тотлыгып: – Ни... мин бит, – дип, авыз эченнән ботка пешерә башлаган иде, Шәмсүн аңа сүз әйтергә бирмичә: – Ычкын моннан, селәгәй авыз! – дип, аяк тибеп кычкырды.* А.Вергазов. **Селәгәй агызып** Кызыгып, ымсынып. --- *мыексыз җегетләр артындин селәгәйләрен агызып йөргән сартларга ияреп, безнең татарлар хатыннарына бөтен мәхлукат файдаланган якты кояшны күрсәтү хәрам дип тә талаштылар.* Г.Тукай. *Намазга утырасы әби-чәбиләр дә хәтта, селәгәйләрен агызып мәгънәсез сериаллар караганда, инде сүнгән нәфес-дәртләрен кузгатып кинәнәләр.* Р.Зәйдулла

**СЕЛӘГӘЙЛӘНҮ** *ф.* 1) Селәгәйгә (*2 мәгъ.*) әйләнү

2) Селәгәй җыелу. *Тешләрне дәвалау бик җиңел түгел шул, сәгатьләр буе авыз ачып утырып, авызың селәгәйләнә, күз алларың караңгылана ---.* Ватаным Татарстан

**Селәгәйләнеп бетү** Бик нык селәгәйләнү. *Әхмәтсафа, селәгәйләнеп беткән авызын җыя алмый, тагы еларга җыенды.* Һ.Такташ

**СЕЛӘГӘЙЛЕ** *с.* Селәгәе булган, селәгәйләнгән. *Хәбирә карчыкның җил капкасы ачык булмаса, [ала сыер] «өйдәләрме?» дигән сыман, зур күзләрен тәгәрәтеп, селәгәйле танавын капкага төртеп ыңгырашып тора иде.* М.Мәһдиев. *Ул селәгәйле авызын чапылдатып үбәргә үрелгәндә генә, сарай чатына сөялгән көрәкне эләктереп, комсызны артка чигендерәм.* Н.Гыйматдинова

**СЕЛӘ́Ү** *и. диал. к.* **селәүчән** (*1 мәгъ.*). *Кармак булгач, селәүчәнсез ярамый, тирес казып, селәү җыйдым.* Н.Әхмәдиев. *Үзеңә карасаңчы, Алмаз Борисович, горком мөдире Кандыр күленә балыкка баргач, кармагына җим, селәү куеп тора идең бит!* Х.Камалов

**СЕЛӘҮСЕН** *и. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан, күбесенчә урманда яши торган соргылт-җирән яки тимгел-тимгел куе йомшак йонлы ерткыч хайван; *русчасы*: **рысь**. *Ә мәнә агач башыннан өскә селәүсен яки каплан сикерүе – куркыныч.* Т.Нәбиуллин. *Мәченең бармаклары аерым-аерым, ә селәүсеннеке элпә белән тоташкан.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр

**СЕЛӘҮЧӘН** *и. зоол.* 1) Яңгыр суалчаннары семьялыгыннан йомшак тәнле, сөяксез, шуышып хәрәкәтләнә торган озынча корт; суалчан; *русчасы:* **дождевой червь**. *Ул салган кармак очындагы селәүчәнне килеп каба.* С.Поварисов. *Канәгать берничә тапкыр үзе ясаган тимерчыбык кармаклар белән селәүчәнгә кармак салып карады – бар, тиз генә каба, ди, сиңа эре балык, ыжламады да.* А.Хәлим. *Селәүчәндәй сыгылмалы, күр әле гәүдәсен...* Р.Сәлим

2) Кешенең һәм умырткалы хайваннарның эчәклегендә яши торган паразит корт; суалчан; *русчасы:* **аскарида**. *Эчең авырта торган була, үзең ябыгасың. Селәүчән авыруы була.* Г.Бәширов

3) Кеше, хайван яки үсемлек организмының эчке органнарында, тукымаларында яшәүче паразит корт; суалчан; *русчасы:* **глист**. *Терлекләрнең организмында яшәүче селәүчән, бабасыр кебек кортларга фән телендә гельминтлар дип әйтәләр икән.* Т.Гыйззәт

**СЕЛЕКМӘ** *и.* Ерткыч балыкны тота торган алдавыч, гадәттә вак балыкка охшатып ясалган, бер яки берничә япьле кармак беркетелгән елтыравыклы калай; *русчасы:* **блесна**. *Кышларын ау үрә, питил бәйли, кышка, кармак салу өчен, селекмә әзерли, кургаштан ялган балыклар коя.* Д.Каюмова

**СЕЛЕ́КТОР** *и. лат.* 1) Бер линиядәге барлык абонентлар белән берьюлы сөйләшергә мөмкинлек бирә, телефон элемтәсе, технологик процесслар һ.б.ш. эшләр белән идарә итүдә кулланыла торган электромагнит автоматы

2) Шундый автомат куелган телефон аппараты. *Урынга утыруга, селектор төймәсе басылды, микрофонда ир кеше тавышы яңгырады: – Тыңлыйм, иптәш командир!* Н.Хәсәнов. *Кинәт директор, калган көтү калган инде, дигән сыман, ашыкмыйча гына селектор аша баш бухгалтерга дәште.* Ә.Сафиуллин

**СЕЛЕКЦИОН** *с.* Селекциягә мөнәсәбәтле. *Алардагы селекцион эш гыйльми нигездә барып, чит ил тәҗрибәләрен дә кулланалар икән.* Ватаным Татарстан

**СЕЛЕКЦИОНЕР** *и. фр.* Селекция белгече, шул өлкәдә эшләүче. *Бакчачы табылган – селекционер!* Г.Мөхәммәтшин. *Анда [теплицада] ниндидер кечкенә машиналар, кешеләр эшлиләр. Селекционерлар, дип аңлатты экскурсовод.* Х.Камалов. *Күптән түгел селекционерлар алтынтуй чәчәгенең культуралы сортларын китереп чыгардылар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**СЕЛЕ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Ясалма сайланыш юлы белән үсемлекләрнең сортларын, хайваннарның нәселен яхшырту яки яңа сортлар һәм нәселләр китереп чыгару эше. *Габделгазиз, үз бәясен белеп, көттереп кенә җавап кайтарды: – Бару бик файдалы булды. Селекция үзәгендә бер карт еврей белән якыннан таныштым.* Т.Галиуллин. *Бүген селекция станциясеннән кайтып барам.* Ш.Шәйдуллин

2) Шул турыдагы фәнни теория. *Аның өчен генетика, селекция, биофизика, микробиология фәннәрен үзләштерергә генә кирәк.* Т.Гыйззәт

**СЕЛЕН** *и. гр.* Техника, пыяла җитештерү сәнәгате һ.б.ш. өлкәләрдә кулланыла торган кара соры төсле уалучан химик элемент. *Селен – кеше организмы өчен иң кирәкле 19 элементның берсе.* А.Әпсәләмова. *Ә көньякка барып кайту безне селен запасы белән тулыландыра.* Татарстан яшьләре

**СЕЛЕНЛЫ** *и.* Составында селен булган. *Селенлы барабаннарның хәлләрен хәл итәм дә шул ук көнне, Ходай кушса, кыз сорарга китәмен.* Р.Харис. *Дөнья базарында селенлы сөтнең бәясе гадиеннән 30 процентка кыйбатрак, ләкин ул шуңа карамастан күбрәк сорала.* А.Әпсәләмова

**СЕЛЕНО́ГРАФ** *и. гр.* Селенология белгече. *Тәҗрибәле селенограф*

**СЕЛЕНОГРА́ФИК** *с.* Селенографиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Селенографик тикшеренүләр*

**СЕЛЕНОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Астрофизиканың Айның табигатен, өслек рельефын тикшерә торган тармагы

**СЕЛЕНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Айны, аның төзелешен, минералогиясен өйрәнә торган фән

**СЕЛЁДКА** *и. рус* Ашамлык булярак сельдь балыгы. *Аннары ул тагын биш былтырдан бирле сатылмыйча яткан краб консервысын да, тозы өстенә чыккан селёдканы да алмакчы булган иде дә, җиңгәчәсе моңа бик каршы төште.* Ә.Еники. *Аннан тагын бәрәңге белән селёдкасына ябышты да кабат башын күтәрмәде [вахтёр].* Г.Мөхәммәтшин

**СЕЛИ́ТРА** *и. лат. хим.* Калий, натрий, аммоний һ.б. кайбер элемент оксидларының тозы (шартлаучан матдәләр һәм авыл хуҗалыгы ашламалары ясауда кулланыла). *Эх, сыек селитра сибеп чыксаң иде, ләкин безнең андый агрегатлар юк.* Х.Камалов. *Селитра эзләү бурычы дары ясау остасы Изги Әюповка тапшырыла.* В.Имамов

**СЕЛКЕГЕЧ** *и. тех.* Селкү, селкеп җилпү җайланмасы, аппараты (гадәттә берәр агрегатта, машинада). *Салам селкегечләр өстендә пар төсле булып ак тузан күтәрелә.* А.Шамов

**СЕЛКЕНЕШ** *и.* 1) Хәрәкәт, селкенү хәле. *Үзенең актыккы селкенеше булярак, ул татар кызын тәрәзә янына илтте.* Ф.Әмирхан. *Ә хәзер танца. Магнитофонны кабыза. Селкенеш башлана.* Т.Миңнуллин

2) Кузгалу, хәрәкәткә килү. *Бервакыт ниндидер бер йогынты яки селкенеш нәтиҗәсендә үзенең исенә килеп төшкән берәр нәрсәне язу теләге туа.* Г.Бәширов. *Тибет монахының сүзләренә колак салыптырмы, башка юрамаларны укыптырмы, күпчелек халык декабрьгә билгеләнгән ахырзаманга ышанмаса да, кешеләр арасында әзме-күпме селкенеш, кыймылдау сизелә.* Шәһри Казан

**СЕЛКЕНМӘ** *с. к.* **селкенмәле**. *Селкенмә кәнәфи*

**СЕЛКЕНМӘЛЕ** *с.* Селкенеп, хәрәкәтләнеп тора торган, атынмалы. *Нижний Новгород каласында Надирша кунакханәсенең парадные. Берничә өстәл, урындыклар, селкенмәле кресло.* И.Юзеев. *Өй баскычының бер як кырыенда селкенмәле бүре карачкысы тора.* Л.Лерон

**СЕЛКЕНҮ** *ф.* 1) Даими һәм кайтымлы хәрәкәт ясау, тирбәлү, чайкалу, калтырау, кыймылдау һ.б. *Әнә тәрәзәдән төшкән яктыда да кара ботакларның, кемнеңдер чатлы-ботлы куллары шикелле, як-якка селкенгәне күренеп тора.* Ә.Еники. *Мондый тавыш әллә нинди кальгаларның капкасын ачтыра ала, әмма Венераның керфеге дә селкенмәде.* Р.Зәйдулла

2) Калтырау, тетрәү, тирбәнү. *Атларның аяк астында җир селкенә.* М.Мәһдиев. *Шулчак җир селкенде, блиндаж түшәменнән аска җәйгән коры печәнгә шыбырдап балчык коелды, барысы да тын калып, снарядның кай тарафкарак төшүен чамалап тордылар.* Х.Камалов. *Экскаватор чуен тукмагы белән шундый итеп китереп ора, җирләр селкенә!* А.Тимергалин

3) Тыныч хәлдән хәрәкәткә күчеп, кыймылдап-кузгалып кую. *Торыйм дисә, гәүдә бөтенләй селкенми.* С.Поварисов. *Ак яулык селкенүгә, атлар томырылып чаба башлый.* Г.Галиева

4) Какшау; нык беркетелмәү яки куба-какшый башлау сәбәпле кузгалырга тору, буш булу. *Кассир кычкыра,*

*начальникның тәҗрибә зур ахрысы, исе дә китмичә, күгәне селкенгән ишекне тотып тора.* А.Гыйләҗев. *Мөгез селкенүнең болай караганда бернәрсәсе дә юк кебек.* М.Әмирханов

5) *күч.* Тигезсез, сикәлтәле юлда, дыңгырдык транспортта тирбәлеп, уңайсыз чайкалып бару. *Малай бертын арба селкенгән уңайга чайкалып барды.* Ф.Бәйрәмова. *– Җиде көн буе вагонда селкенгәннән соң, каты җирдә әллә ничек хис итәсең икән үзеңне, – диде Галия, командирга кулын сузып.* Ф.Әһлиуллина

6) *күч.* Бераз активлык күрсәтү, тырышлык кую. *Болай ялкауланып эш бармас, селкенергә кирәк, иптәшләр.* И.Нуруллин

7) *күч.* Талчыгу, хәлсезләнү яки иренү сәбәпле, җиңелчә генә эшләү (гадәттә физик хезмәт тур.). *Анысы шулаен шулай да, әмма Зариф кебекләр дә эшләгән булып селкенеп йөриләр, андыйларга да язарлар, ә бәрәкәте ни?..* Ә.Еники. *Укыдым дип... Йөрдем инде шунда ДОСААФ бинасында селкенеп.* Ә.Рәшит. *Аннары ишәк кебек тик йөрисең шунда селкенеп.* И.Шиһапов

8) *күч. ирон.* Эшләгән кыяфәт чыгару. *Нуриман абзый кем кирәген өзеп кенә әйтеп бирә алмагач, монда торырга ярамаганын, эшсез селкенгән кешеләрне полиция җыеп алып китәчәген хәбәр итеп, контор яныннан иплән кенә озатып җибәрделәр.* Г.Ахунов. *Дөрес, бик сак эш итеп кенә, милли хәрәкәт басымы астында рәсми мәгариф тә берникадәр селкенде.* И.Әмирханов

**Селкенә башлау** Селкенергә тотыну. *Гыймади тагын селкенә башлый.* Г.Исхакый. *Тезгеннәр тартыла, камчылар уйный, өзәңгеләр селкенә башлый.* Г.Ибраһимов

**Селкенә бирү** Бернигә дә карамастан һаман селкенү. *Шуннан соң ишан хәзрәтләре тәсбих элгән кулын күтәреп, селкенә биреп, бик озын итеп дога кыла.* Ә.Еники. *Кабарынкы мендәренә сеңеп утырган да, оеп, гамьсез генә селкенә бирә.* А.Вергазов

**Селкенеп алу** Кыска вакыт эчендә яки тиз арада селкенү. *Гайнан кепкасын басыбрак киде, селкенгәләп алды.* Г.Бәширов. *Башта карчык та әллә ни борчылмаган кебек: – Ара-тирә селкенгәләп алу зарар итмәс, бераз килере дә булыр, – дигән иде.* М.Шабай

**Селкенеп китү** Кинәт, кисәктән селкенү. *Мәүлиханың түгәрәкләнеп уелган матур борын канатлары түземсезлек белән селкенеп китә.* Г.Бәширов. *Тавышы бөтен җәйләүгә, аннан төнге далага таралды, әрәмә куаклары селкенеп киткәндәй булды.* Г.Госман

**Селкенеп кую** Бер мәртәбә селкенү. *Габбас мулла өстәл янында селкенеп куя.* Г.Ахунов. *– Исәнмесез, иптәшләр, – диде көр тавыш, һәм куян бүрек селкенеп куйды, тирә-якка кар чәчрәде, – бәйрәм котлы булсын.* И.Салахов

**Селкенеп тору** Озак, даими рәвештә яки хәзерге моментта селкенү. *Кайтышлый, Дүртөйле очында, Димнән якында гына нефть чыгаручы ике качалканың ашыкмыйча гына бер җайга селкенеп торуларын күрдем.* Ә.Еники. *Аның бер погоны каядыр төшеп калган, икенчесе дә, менә төшәм, менә төшәм дигәндәй, көзге усак яфрагыдай селкенеп тора.* А.Әхмәт

**СЕЛКЕНЧӘК** *с.* **1.** Селкенеп, калтырап тора торган. *Шул чагында Таҗиткә Әүфил сынчының сүзе дә, йөзе-кыяфәте дә Төпсез чүлмәк чүплегендәге селкенчәк җир кебек бик-бик шикле һәм ышанычсыз тоелды.* Н.Фәттах. *Болар – суверенлык өчен көрәшнең иң активистлары: аксак-туксак, күрәкарау, селкенчәк, җилсу, чагыр, ярсу микроблар иде.* М.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **койка**. *Әби балык шулпасы һәм балык селкенчәге белән сыйлады.* Х.Мөҗәй

2) *зоол. сөйл.* Чәперчек кошлар семьялыгыннан озынча гәүдәле, нәзек аяклы, койрыкларын даими рәвештә селкетеп тора торган кош; чәперчек, сиртмәкойрык; *русчасы:* **трясогузка**. *Тәкәрлек белән Селкенчәк сазлы-мүкле урыннарда торак җиткергәннәр.* Әкият. *Күп тә үтмәде, чишмә суы коелган җиргә юеш таш түмгәкләренең берсенә селкенчәк килеп кунды.* Р.Батулла

**СЕЛКЕТҮ** *ф.* 1) Төрле якка атындырып, кыймылдатып яки бүтәнчә хәрәкәтләндерү. *– Селкет кулыңны, бармакларыңны җәһәтрәк йөрт, кан тизрәк төшәр, – дип, мыскыллап киңәш бирде.* М.Хуҗин. *Тау селкетерлек баһадир иде, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын.* Н.Гыйматдинова

2) Тирбәтү. *Үзем бишек селкетәм, үзем сине уйлыйм, уйлыйм да елыйм.* Сөембикә

3) Калтырату, тетрәтү, дерелдәтү. *Янгынчының еларга җитешеп кычкыруына каршы, ни хикмәт диген, бөтен авыл, бөтен якын-тирәне селкетеп, калтыратып шаркылдап җибәрде.* Ә.Баян. *Кайсыдыр бер язны – утыз дүртенче елнымы икән – басу түренә, җир селкетеп, трактор килеп туктады.* М.Мәһдиев

4) Сикертеп-калтыратып яки чайкалдырып борчу (дыңгырдык юл һәм транспорт тур.) // *з.-сыз* Транспортның яки юлның сикертеп-калтыратып яисә чайкалдырып тирбәтүе-борчуы турында. *Поездда нык селкетте.* Н.Гыйматдинова

**Селкетә башлау** Селкетергә керешү. *– Әй, бала, бер генә минутка тор әле, зинһар, – диде Фәләх һәм, кулын иплән кенә Гасимәнең иңенә куеп, аны селкетә башлады.* В.Нуруллин

**Селкетеп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә селкетү. *Өстәл астында утырган ак песи колакларын селкетеп алган арада, Фәрит базга төшеп чумды.* Ф.Шәфигуллин. *Аны әледән-әле тарих чүплегеннән күтәреп чыгарып, безнең алда селкетеп алалар.* Р.Зәйдулла

**Селкетеп карау** Тикшерү-белү максаты белән селкетү. *– Нык ямаган миңа бу хәшәрәт, – диде ул, бер тешен селкетеп карагач.* А.Тимергалин

**Селкетеп кую** Бер тапкыр селкетү. *Айтуган карт торып китте дә, бакча рәшәткәсенә таянып, нидер уйланып алды, гүя көчен чамалагандай, иңбашларын селкетеп куйды.* Г.Бәширов. *Балыкның зур ачылган күзләре әллә гаҗәпләнүдән, әллә дымлы җилдән ялтырый башлады, ул, сизелер-сизелмәс кенә, койрыгын селкетеп куйды.* Ф.Зариф

**Селкетеп тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында селкетү. *Су аларны әкрен генә чайкый, бүрәнәләр өстенә утыртып куйган сарылы-*

*зәңгәрле ике өйне, --- мәтеләр белән бергә селкетеп тора иде.* Г.Ахунов. *Иңбашыннан эләктереп алып, озак кына селкетеп тордым.* А.Гыйләҗев

**СЕЛКҮ** *ф.* 1) Тузанын, чүбен һ.б.ш.ларны кагып төшерү өчен, кискен хәрәкәт белән болгау, селтәү, җилпү. *Хәер, ападан бер ишетеп калган идем: базарда, имеш, чи тиреләрдән селкеп җыйган нафталинлы тоз саталар, дип...* Ә.Еники. *– Әй, шушы, – дип карлы шәлен салып селкеде Гөлфиянең әнисе, – кыланып йөри шунда!* Ф.Шәфигуллин. *Өстегезне кагыгыз, селкегез, юыныгыз, әнә сезгә Кармыш инеше.* З.Зәйнуллин

2) Капчык, савыт һ.б.ш.ларның авызын, өстен түбән караткан хәлдә кискен болгап, селтәп яки җилпеп, эчендәге әйберен бушату. *Лениза өйгә керде дә, сумкасын ачып, эчендәге бар нәрсәне өстәл өстенә селкеде.* М.Маликова

3) Очу өчен канатны хәрәкәтләндерү, җилпү. *Якыннан гына очып үткән юеш карганың авыр гына селеккән канат тавышы ишетелеп кала.* Ә.Еники

4) Болгау, төрле якка хәрәкәтләндерү. *Саубуллашып яулык селеккән күк Сызылып калды Казан төтене.* Х.Туфан. *Песи, аны аңлаган сыман, мырлый-мырлый койрыгын селки иде.* А.Гыйләҗев. *[Мәче] Пычракка баскан саен, җирәнгән кебек, алмаш-тилмәш аякларын селки.* Г.Сабитов

5) Изәү, берәр ишарә хәрәкәте ясау. *Алар киткәч, эшләүчеләрнең өсләреннән авыр йөк төшкән кебек булып калды, һәм, алар ераклаша төшү белән, һәркем эштән туктап, әрле-бирле селкеп, талган кулларын яздылар...* М.Гафури. *Кечкенә буйлы, павиан токымыннан булган маймылныкына охшаш йөзле малай, бу сүзләрне раслап, башын селкеде.* Р.Зәйдулла

6) Болгау, җилтерәтү, селкетү. *Сумкасын селкеп, Зәнә керә, әти-әнисен күреп туктый.* А.Гыйләҗев. *Дөньяның читенә чыгар идем дә утырыр идем аякларымны селкеп!* Х.Ибраһим

7) *к.* **селкетү** (*4 мәгъ.*). *Олы юлга кергәндәге чалуда чананы шулкадәр нык селкеде ки, икесе тиң юл читенә тәгәрәп төштеләр.* Р.Низамиев

**Селкә башлау** Селкергә керешү. *Күлмәкне калдыргач, без кинога барасы идек, Илһам урамда көтеп тора, ә мин йөгереп аска төштем, бәләкәй кулларым белән егетнең изүеннән умырып тоттым һәм бар көчемә селкә башладым: – Маша нәрсә ди ул?* Н.Гыйматдинова

**Селкә бирү** Селкүне дәвам итү, озак вакыт селкү. *Сырлы таягын селкә биреп, Дәүләкәннең кибетләре арасыннан узганда, һәркемнең дикъкатен үзенә җәлеп итә торган иде.* Ә.Еники

**Селкеп алу** Тиз генә, бераз селкү. *Чү, Газраил канатларын селкеп алды, Таратты бар болытларны офыкларга...* Һ.Такташ. *Николай чулак кулын селкеп алды.* И.Салахов. *Сүзләренең дөреслеген расларга теләгәндәй, ул кулындагы бөгәрләнгән кәгазен Гобәйдулланың борын төбендә селкеп алды.* Н.Гыйматдинова

**Селкеп җибәрү** Кинәт кенә селкү. *Бераз җир киткәч, кече сеңелләре, бакыр сарайга таба карап, кулъяулыгын селкеп җибәрә.* Әкият. *Башын селкеп җибәрүгә, елкылдап торган элекке матур чәч толымнары урынына, төптән кысып бәйләгән койрык сыман шыксыз бер нәмәстә айкалып китте.* Г.Бәширов

**Селкеп кую** Бер тапкыр селкү. *Күк байтал исә, бу тынгысыз кызның бертуктаусыз дилбегә тартып мазасызлавына эче пошып: «Әй, теш корты булдың иң тамަнысы!» – дигәндәй, дилбегә тартканга койрыгын гына селкеп куя иде.* Г.Бәширов. *Хатын, «әйе» дигәндәй, башын селкеп куйды.* Р.Зәйдулла

**Селкеп тору** Озак вакыт дәвамында, даими яки сөйләү моментында селкү. *Әти башын селкеп торды да: – Түзми нишлисең инде. Башыңны ташка орасыңмыни?! – диде.* Г.Бәширов. *– Вәт, ичмасам, яши кешеләр! – дип, кызыл фәсле башын озак кына селкеп торды [Фатих хәлфә].* Г.Ахунов

**СЕЛТӘНЕШ** *и.* 1) Селтәнү (*1, 2 мәгъ.*) хәрәкәте. *Көчле селтәнеш белән бәрү*

2) *күч.* Тәнкыйть белән каршы чыгу, рухи һөҗүм. *[Шагыйрь иҗатының беренче елларын танымаска өндәү] – гүзәл башлангыч чорны бер селтәнүдә сызып ташлау дигән сүз. Кыюлыгы белән бер үк дәрәҗәдә мәгънәсез селтәнеш!* М.Максуд

**СЕЛТӘНҮ** I *ф.* 1) Кул яки корал белән селтәү хәрәкәте ясау. *Тик аңа [Шамилгә] җиңелрәк эш таптылар: усал күршегә селтәнергә дә, кизәнергә дә ярамый иде.* Н.Гыйматдинова. *Теге ярда бер ир-ат чалгысын кулга алды, янады, аннары, кискен генә селтәнеп, печән чаба башлады.* Р.Зәйдулла

2) Сугарга, бәрергә кизәнү. *--- конвойчы карт Галләмовка мылтык түтәсе белән селтәнгән иде, тегесе агарынып, яралы битен кулы белән каплады.* Г.Ахунов. *Илдархан, нәфрәтен дә кулына күчереп, тагын селтәнеп сукты, Ятманов сыгылырга өлгергәнче, аны җан көченә этеп җибәрде.* М.Хуҗин

3) *күч.* Һөҗүм итәргә тырышу, каршы чыгу, тәнкыйтьләү. *Теге адәм Фрунзега селтәнгән икән. Болай да сызланып яткан яралы хайван, ачыргаланып, кызыл йөзленең арт саныннан умырып тешләп тә өлгергән иде.* Д.Бүләков

4) *күч.* Хәлдән килмәстәй кыен эшкә алыну, берәр нәрсәгә ирешергә омтылу. *Чит ил машинасына селтәнү*

**Селтәнеп алу** Бер тапкыр, тиз генә селтәнү. *– Дәшмә! – Идрис сөякчел куллары белән һавада селтәнеп ала.* Ф.Бәйрәмова

**Селтәнеп җибәрү** Көтмәгәндә селтәнү. *Ул атын кырт кына уңга борды, әле һаман авызы ерык Төпсәнең каршысына килеп басты, кыныдан кылычын тартып алды да бар көченә селтәнеп җибәрде.* Н.Фәттах

**СЕЛТӘНҮ** II *и.* 1) Кизәнү, изәү, селкү хәрәкәте. *Учларын читкә каратып селтәнүе «күземнән югал, кит» дигәнне аңлата иде булса кирәк.* Ф.Латыйфи. *Билгеле бер санда селтәнү ясагач, ятьмә капчыгын кинәт кенә кыршау аркылы ташлыйлар.* Яшь натуралистларга

2) *күч.* Эш-хәрәкәт, гамәл. *Мөмкинме соң бер селтәнү белән Бөтенесен кире борырга?!* Ә.Рәшит. *Шулай ук каләм әһелләре үзләре дә бер селтәнү белән*

*дингә булган хөрмәттән аерылып бетә алмыйлар, аларның күңел дөньясында моңа каршылык бар, вакыт-вакыт ул үзен сиздереп тә куя.* Ф.Галимуллин

3) *күч.* Каршы чыгу гамәле, һөҗүм. *Киләчәктә ничек булыр, Шамкаевның Марсельгә биргән бәясе Марсель рухына беренче тапкыр селтәнү булды.* Т.Миңнуллин. *Хәләл акчаңны түләп язылган журналның үз вакытында килеп җитмәвен матбугатирегенә селтәнү рәвешендә кабул итәргә кирәктер?!* Р.Фәйзуллин

**СЕЛТӘ́Ү** *ф.* 1) Болгау, селкү. *Чәнси, йөгереп килмәкче булып, артына чигенде, ләкин, шуны гына көтеп торган сыман, ырылдап, кулларындагы артыш таякларын селтәп, шундук аны камнар уратып алды.* Н.Фәттах. *Мөәзкир, чалгыны җәйлап тотып, уңга-сулга селтәп, һава телде: чалгы җиңел, кулда сызгырып кына йөри!..* А.Гыйләҗев

2) Кизәнеп болгау. *Әгәр дә карчык, ачуланып, котырып, йотмакчы булса, бу батырлар (егетләр), кылычларын бер селтәү белән, убырлы карчыкның гомерен кыскарталар.* К.Насыйри. *Солтан Мөгыйннең артына борылып каравын, ат өстеннән күтәрелә төшеп, уңлысуллы камчы селтәвен күрде.* Г.Ахунов

3) Изәү. *[Хәмдия] ишектән башын тыгып, Бакыйга кул селти.* М.Фәйзи. *Артыма борылдым да Госманга кул селтәп кычкырдым.* Ф.Хөсни

4) Җилпеп селкү, кагу (канатны һ.б.ш.). *[Акчарлаклар] ак канатларын селтәп-селтәп, бер югары, бер түбән очып --- кычкырыналар.* Ш.Камал

5) Ыргыту, чөю. *Ир казыгын селтәү белән, Бүдәнә оча да хатынның савып торган сыерының мөгезенә килеп куна.* Әкият. *[Шаһтимер] ташны көтүгә таба селти.* М.Фәйзи. *Күз ачып йомганчы малайлар [көрәшүчеләр] берберсен селтиләр дә ыргыталар, селтиләр дә ыргыталар. Бер егучыга унлабы сикереп тора.* Ә.Еники

6) Кизәнеп, селтәнеп сугу. *Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем.* Ф.Хөсни. *Әнисе, ачуланып, чыбык алды да: – Кит әле, каймакны пычратма син! – дип, песигә берне селтәде.* Д.Аппакова

7) Егу, очыртып җибәрү. *Көтелмәгән җирдән Әптелбәр атылып чыкты да Габдулланы үчекләп торучы малайлар өстенә ташланды, аларны уңлысуллы селтәп ташлады.* Ә.Фәйзи

8) *күч.* Кулга төшерү, эләктерү. *Егет кенә түгел, карчыга ул безнең кияү. Шулай булганга күрә илдә бер булган Маһруйны селтәде дә.* М.Фәйзи. *Канатларын җитез селки ул [акчарлак]. Вак хамсаны [балыкны] бик тиз селти ул.* К.Нәҗми

9) *күч.* Урлау, шудыру, чәлдерү. *Малай чакны шулай берәүдән каеш чыбыркы селтәп кайттым.* А.Расих. *Тоташ урлашу, селтәү, сыртка салу, чәлдерү, үзләштерү.* Татарстан яшьләре

**Селтәп алу** Тиз генә, бер тапкыр селтәү. *[Алып баручы] Залда утыручыларның берсенә ишарә ясагандай, кулын селтәп алды да шигырь укый башлады.* Ф.Баттал

**Селтәп җибәрү** Кискен хәрәкәт белән селтәү. *Ул арада күк көтүчесе уттан үргән яшен камчысын дә селтәп җибәрде: урман эчләре ялт-йолт итеп китте.* Г.Әпсәләмов. *Исәнтәй аларны як-якка җиңел генә селтәп җибәрде дә каганның аягы астына барып егылды.* Н.Фәттах

**Селтәп кую** Бер мәртәбә селтәү. *Ләкин аның гадәтен зимагурлыкта йөргән чактан ук белә: фәһем алырдай сүз булса – тыңлый, рухына туры килмәсә, я бөтенләй эндәшми, я кулын гына селтәп куя.* С.Поварисов. *– Ю-у-к! – дип, кулын селтәп куйды Галиулла.* К.Тимбикова

**СЕЛТЕ** 1) *и.* Берәр тоз белән кислота кушылуыннан барлыкка килгән зәһәр химик матдә. *Аппаратның бункерына тимер вагы ташладылар, Олдридж. Ә дистилляторга зәһәр селте салынган...* А.Тимергалин. *Берләшмәгә үткәч, гальваника цехы үзен шундук белдерде: селте парлары белән аралашкан әчкелтем һава борынны ярып керде, тамак төбен әчеттерде.* Н.Хәсәнов

2) Агач көле салып кайнатылган, кер юу өчен файдаланыла торган эремә. *Хуҗа хатын да аннан өметен өзде: элекке кебек куе каймак та эләкми егеткә хәзер, бәрәңге дә ярмалап пешми, мендәр тышыннан селте исе килә, яккан мунчасы исле, идәне сап-салкын була.* А.Гыйләҗев. *Бу юлы бигрәк агартып югансың, дип әйтимме... Әллә селте суыннан шулай агардылар микән?* Г.Галиева

**СЕЛТЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Селтегә әйләнү (көл һ.б.ш. тур.). *Районның төньягында – соры урман туфрагы, Буадан көньяккарак селтеләнгән кара туфрак өстенлек итә.* Татарстан Республикасы: кыскача географик белешмәлек

2) Составында селте күләме арту (су, туфрак һ.б.ш. тур.)

3) *күч.* Усаллану, зәһәрләнү. *Агымда булмауны сизеп, Селтеләнеп ачынудан Анда башка омтылышлар, һәм бүтәннәр бара алда.* Р.Харис

**СЕЛТЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Селтеле итү, селте катнаштыру. *Карагайның үзе үсә торган тирәлеккә йогынты ясый торган бик кызык үзлеге бар: чыршыдан аермалы буларак, аның ылыслары, череп таркалганда, туфракны селтели.* Татарстанның хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы

2) Селте белән эшкәртү. *Вак күмер тузаны тирене тишеп керә дә, селтеләп юсаң да, тәнне агартып булмый.* М.Юныс

**СЕЛТЕЛЕ** *с.* 1) Составында селте булган, селте салынган, катнаштырылган. *Аларның поташ (көлдән ясала торган селтеле матдә) заводлары да, кәгазь фабрикалары да, пыяла заводлары да булган.* С.Алишев. *Матдәнең гидролизы нәтиҗәсендә, эремәдә әче, селтеле яки нейтральгә якын тирәлек барлыкка килә.* Гидролиз

2) Селте белән эш итә торган. *Әнисе хромлаштыруда, гомере буе селтеле цехта эшләгән, пенсиягә чыкканчы ук авырып киткән.* Н.Хәсәнов

**СЕ́ЛЬВА** *и. лат.* Көньяк Американың дымлы тропик урманнары. *Шулай гөрләп торган калаларны йөз ел вакыт үтүгә сельва йота.* Ә.Дусай. *Монда аны «сельва» дип атыйлар, португалиялеләр телендә ул «урман» дигәнне аңлата.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Сельва Африка урманнарыннан шактый дымлырак, үсемлекләр һәм хайваннар төрләренә дә байрак.* География

**СЕЛЬДЕРЕЙ** *и. гр. бот.* Тамыры һәм яфрагы аш тәмләткеч итеп файдаланыла торган икееллык үсемлек. *Каз муеннары сельдереймы, петрушкамы белән бизәлгән.* М.Мәһдиев. *Зәнфирә өстәлгә суган-сарымсак, сельдерей, укроп исләре килеп торган кып-кызыл борщ китереп куйды: – Әйдә, аша, хәзер сиңа кайнар шулпа кирәк.* Ф.Садриев

**СЕЛЬДЬ** *и. бор. сканд. зоол.* Сельдьчәләр семьялыгыннан бик эре булмаган, күбесенчә диңгездә яши торган промысел балыгы. *[Шәрәфи агай] Берничә елдан бирле сельдь вакытында хуҗаларның шушы промыслосында ай ярымнар чамасы балык тозлау эшендә тора иде.* Ш.Камал

**СЕЛЬКУП** *и.* Көнбатыш Себердә яшәүче, самоед телләренең берсендә сөйләшүче халык һәм шул халыкның бер вәкиле. **---** *борынгы мисыр, солон, эвенк телләрендә му – «су», селькуп телендә ну «күк» --- дигәнне белдерә.* Н.Фәттах. *Ерак Төньякта, Таз елгасы бассейнында һәм Таймыр ярымутравында селькуп дигән кечкенә халык яши.* Р.Әхмәтьянов

**СЕЛЬПО** *и. рус* 1) Авыл җирендә сатып алучылар җәмгыяте. – *Безнең сельпо машинасы, – диде Зөһрә.* Х.Сарьян. *Райпотребсоюзга, сельпога товар ташучылар кышлыкта бу араны ике көн йөриләр иде.* А.Хәсәнов

2) Шул җәмгыятькә караган кибет

**СЕ́МА** *и. гр. лингв.* Лексик мәгънәнең иң кечкенә, бүленми торган өлеше. *Статик халәттә сүзнең лексик табигате (сема) сүзлекләрдә теркәлә торган реаль сүз мәгънәсе белән билгеләнелә.* Фән һәм тел

**СЕМА́НТИК** *с. лингв.* Семантикага мөнәсәбәтле. *Семантик яктан караганда, грамматик категория – бердәй грамматик мәгънәләр җыелмасы.* Ч.Харисова. *Структур һәм семантик үзенчәлекләрен искә алып, бер составлы җөмләләр өчкә бүлеп өйрәнелә: фигыль җөмлә, исем җөмлә һәм сүз җөмлә.* Р.Шәмсетдинова

**СЕМА́НТИКА** *и. гр. лингв.* 1) Сүз, идиома, сүзтезмә, җөмлә һ.б.ш. категорияләрдә мәгънә. *Бу – семантикасы белән «сака ирләре» дигән сүз була.* М.Зәкиев. *«Албастылар» әсәрендә сынау һәм котылу семантикаларына нигезләнгән мотив – үзәк мотивларның берсе.* А.Шәмсутова

2) *к.* **семасиология**. *Рус теленә күчү татар теленең төрле тармакларында (фонетика, лексика, морфология, синтаксис, семантика) һәм төрле формаларда күзәтелергә мөмкин.* Фән һәм тел

**СЕМАСИОЛО́ГИК** *с. лингв.* Семасиологиягә мөнәсәбәтле. *Лексик-семантик вариантлылык ул – сүз мәгънәнең эчтәлегендә билгеле бер аерымлану хасил булу, семасиологик полисемия күренеше дип аңлатыла.* И.Бәширова. *Татар телендә яңа техник атамалар формалашу чорында терминнарга семасиологик анализ уздыру зур әһәмияткә ия, һәм моны тел белгечләре техник фән галимнәре белән бергәләп башкарырга тиеш.* Фән һәм тел

**СЕМАСИОЛО́ГИЯ** *и. гр. лингв.* Тел белеменең сүзләр, идиомалар, аерым тел берәмлекләре – сүзтезмәләр һәм җөмләләрнең мәгънәләрен тикшерә торган тармагы. *Телнең мәгънә ягын тикшерсәк, ул грамматика түгел, семасиология булып китәргә тиеш.* Г.Алпаров. *Сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен, үзгәрешен өйрәнә торган тармак семасиология (грек. seme – мәгънә, logos – өйрәнү) дип атала.* Ф.Сафиуллина

**СЕМАФОР** *и. гр.* 1) Тимер юлда багана, колга һ.б.ш. башына куелган механик сигнал җайланмасы. *Бер унбишегерме минут үтүгә, семафор ягыннан күкрәген киереп килгән гайрәтле кара паровоз күренә.* Ә.Еники

2) *сир. күч.* Рухи капка, күңел капкасы. *Үткәрми «тара-бара»ны Киләчәк көнгә халык. Юк, аңа халык җанында Семафор ябык, ябык!* Х.Туфан

**СЕМӘК** *и.* Баш киеме түбәсенең очлаеп торган урыны. *Аның башында семәк очлы чалма бүреге, кулында калын гына имән таягы, чырае алмашынган иде.* Ш.Камал

**СЕМЕ́МА** *и. гр. лингв. к.* **сема**

**СЕМЕСТР** *и. лат.* Югары һәм махсус уку йортларында уку елының бер яртысы. *Беренче семестр азагы якынлашып, имтиханнар бирер вакыт җитте.* Ә.Хәсәнов. *Әмма мин беренче курсның танышу семестрында бәрәңге алуда катнаша алмый калдым.* И.Нуруллин. *Шөкер, беренче семестрны уңышлы гына җиңеп чыктым.* Г.Галиев

**СЕМИНАР** *и. лат.* 1) Студентлар төркеменең берәр фән буенча практик эш дәресе. *Хәлбуки Моратовның университетка катнашы бик аз, ул бер курста семинар дәресләре генә алып бара иде...* А.Гыйләҗев. *Мин бүген йокыдан соңрак тордым, кичә семинарга озак әзерләндем.* Р.Сабиров

2) Берәр махсус темага багышлап, аны тирәнтен өйрәнү өчен, төркем белән үткәрелә торган белем күтәрү чарасы. *Менә шул институт каршында берзаман, психотехниклар хәзерләп чыгару өчен, бер еллык семинар оештырыла.* Ә.Еники. *Ә бер көнне мине тарих укытучыларының семинарына шәһәргә җибәрделәр.* М.Мәһдиев

**СЕМИНАРИСТ** *и. рус* Семинария укучысы. *Тагы Пулин фамилияле бер семинарист та бик каты кыйналды.* Г.Тукай. *Адвокат, берничә семинарист, студент казакълар хәйран булып, якында стражник юкмы дигәндәй, як-якка карандылар.* Г.Ибраһимов

**СЕМИНА́РИЯ** *и. лат.* 1) 1917 елга кадәр Россиядә урта педагогик уку йорты. *Без инде кайтып та җиткән идек. Семинария каршысында тукталдык.* Ә.Еники. *[Солтанны] Алабугага, учительский семинариягә бирергә исәп.* Г.Ахунов. *Алты елдан соң училище семинария итеп үзгәртелә.* Татар халкы һәм Татарстан тарихы

2) Православие руханиларын әзерли торган урта уку йорты. *Алга таба христианлаштырылганнарны семинарияләргә алырга, әмма алар беркайчан да ана телен онытмаска тиеш, һәм, иң мөһиме, урыс булмаган телләрне өйрәтүне кертергә кирәк!* Р.Батулла. *Мәсәлән, Нижний Новгородтагы духовная семинария епископы Дамаскин 1785 елда русча-татарча-чувашча-мордвача-марича сүзлек бастырып чыгарган.* Ф.Сафиуллина

**СЕМИОЛО́ГИК** *с. к.* **семиотик**

**СЕМИОЛО́ГИЯ** *и. гр. к.* **семиотика**. *Беләбез, Ф. де Соссюр үзе дә, аның шәкертләре дә, алардан соңгы*

*лингвистлар, шул җөмләдән татар телчеләре дә, телне семиология (тамга, знакларны өйрәнү фәне) юнәлешендә тикшереп, аның структурасын җентекле ачыкларга күп хезмәт сарыф иттеләр.* И.Низамов

**СЕМИО́ТИК** *с.* Семиотикага мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Шулай булуга карамастан сәнгатьнең семиотик функциясе доминант функцияләрнең берсе булып каралырга хаклы.* К.Гыйззәтов. *Алар исә, үз чиратында, мәдәниятнең теге яки бу үзгәреше чорында хакимлек иткән семиотик (әйбер белән аның билгесе арасындагы) мөнәсәбәтләргә бәйле.* Философия

**СЕМИО́ТИКА** *и. гр.* Шартлы яки шартсыз хәбәр, мәгълүмат чыганагы булган, нинди дә булса бер мәгънә белдергән билгеләр, тамгалар, сигналлар, эзләр һәм аларның системалары турындагы фән. *Сәнгать әсәрләрен тикшерү эшендә семиотика (билгеләр турындагы фән) методларын механик рәвештә куллану да акланмас иде.* К.Гыйззәтов. *Семиотика фәне барлыкка килгәч, әдәбият белемендә «образ» төшенчәсе белән янәшә «билге» (знак) термины активлашты.* А.Батталова

**СЕМИТ** *и. фр.* Алгы Азиянең, Төньяк һәм Көнчыгыш Африканың бер өлешен биләп яшәүче яһүд, гарәп һ.б.ш. телләре үзара якын булган тугандаш халыклар төркеме һәм шул халыкларның бер вәкиле; сами. *Ул картвель телләренең семит, баск телләре белән уртаклыгы турында фәндә факт белән беркетелмәгән теория уйлап чыгарган икән...* М.Мәһдиев. *Дөньяда һинд-европа, семит, фин-угор, дравид, кытай-тибет, банту, кавказ һ.б. тел семьялары бар дип исәпләнелә.* Н.Фәттах

**СЕМИТО́ЛОГ** *и.* Семитология белгече

**СЕМИТОЛО́ГИЯ** *и.* Семит телләрен һәм мәдәниятен өйрәнә торган фән тармагы

**СЕМЬЯ** *и. рус* 1) Ата-ана белән балаларның, кардәшләрнең һәм бүтән якын кешеләрнең бергә яшәүче төркеме; гаилә. *Сезнең семьяга өченче берәү катнашып, ышанычыгызны, өметегезне өзгән дип аңларгамы?* С.Баттал. *Гомере буе семья, бала-чагасын кайгыртмады.* М.Мәһдиев

2) Җәмгыятьнең шундый төркемнән гыйбарәт иң кечкенә берләшмәсе, ячейкасы. *Мин булачак семья ячейкасы исеменнән шелтә чыгардым.* Ә.Фәйзи. *Шуңа күрә күбесе анда ялгыз марҗаларга йортка кереп, семья корып диярлек яши, кайсысының инде идәндә тәгәрәшеп балалары да йөгереп йөри.* Р.Зәйдулла

3) *күч. кит.* Уртак эш, уртак максат хакына берләшеп дус яшәгән кешеләр төркеме; тату коллектив. *Аның исәлегенә колхозыбызны «Байчурин» колхозы дип атаганнар. Без хәзер сугышып тормыйбыз, бер семья булып яшибез.* А.Алиш. *Бәйрәм белән, хезмәт халкы, Хезмәт семьясы, Коммунарлар, баһадирлар Династиясе!* Х.Туфан

4) Берояда туган һәм шунда үстерелә, асрала торган кош-корт яки хайваннар төркеме; оя. *Шуларны исәпләп карасаң, бер семья корт кына да никадәр эш башкара.* Ф.Яруллин. *Тик, карап торам, умарта семьяларым көчле.* А.Хәсәнов

5) *лингв.* Кардәш телләрнең иң зур төркеме. *Төрки телләр дә аерым кардәшлек семьясы тәшкил итәләр.* Н.Фәттах

**СЕМЬЯЛЫ** *с.* Семьясы (*1 мәгъ.*) булган, семья белән яшәүче; гаиләле. *Монда семьялы кешеләр генә тора.* М.Гафури. *Аннан соң штурман, гадәттә, семьялы кеше була.* М.Юныс. *Якшәмбе көннәрендә семьялы иптәшләреннән кем өчен булса да дежурлык итәргә үзе теләп ризалык белдерә иде.* Р.Батулла

**СЕМЬЯЛЫК** *и.* 1) *биол.* Үсемлек һәм хайваннар дөньясында төзелешләре охшаш һәм чыгышлары ягыннан үзара якын берничә төрне берләштергән төркем. *Аның [миләшнең] җимешләре нәни алмаларга охшаган, ә бу юкка түгел, алар бер семьялыктан.* Ф.Ибраһимова. *Мәче танылган ерткычларга – юлбарыс һәм хайваннар патшасы арысланга – «туган» туры килә, чөнки алар бер семьялыктан.* Табигать бизәкләре

2) *лингв. ялг. к.* **семья** (*5 мәгъ.*). *Алтай телләре, үз чиратында, фин-угор һәм дравид тел семьялыкларына якын торалар.* Р.Әхмәтьянов

**СЕМЬЯСЫЗ** *с.* Семьясы булмаган, өйләнмәгән яки кияүгә чыкмаган. *– Семьясыз кешегә уңайсыз булмасмы соң? – диде Шәрәфи карт.* Ш.Камал. *Гомерең кыска булсын, кайгы-хәсрәттә, авыртуда, хәерчелектә яшә, семьясыз гомер буе хәсрәт күр, бәладә яшә!* М.Кәбиров

**СЕМЬЯЧЫЛ** *с.* Семья яратучан, аны кайтыртучан; гаилә җанлы. *Митрий – бик семьячыл кеше, район үзәгенә барганда, рәсми оешмалар белән эшен тәмамлауга, промтоварлар кибетенә керә һәм бала-чага өчен кием сайлый.* М.Мәһдиев

**СЕНАЖ** *и. рус* Яшел үләнне герметик ябык урыннарда 50–55% дымлылыгын саклаган хәлдә ваклап, пресслап әзерләнгән мал азыгы. *Мотоцикл белән сенаж башнясы янынн үтеп барганда, башка бер уй килде әле.* Р.Сәлим. *Аннан ияреп кайткан сенаж, силос исләре бөтен киемгә сеңеп бетә.* А.Әхмәтгалиева

**СЕНАЖЛА́У** *ф.* Яшел массаны, тиешле таләпләргә туры китереп саклау өчен, махсус урынга тутыру

**Сенажлап бетерү** Барысын да сенажлау; сенажлауны төгәлләү

**Сенажлый башлау** Сенажларга керешү

**СЕНАТ** *и. лат.* 1) Борынгы Римда иң югары дәүләт органнарының берсе. *Борынгы римлылар Карфаген белән сугышканда, Катон дигән бер патриций Рим сенаты утырышында һәрвакыт речь сөйли икән.* М.Мәһдиев

2) Элекке Россиядә югары хөкемсуд инстанциясе сыйфатында шикаятьләрне карый торган һәм дәүләт аппаратына күзәтчелек итә торган хөкүмәт органы; санат. *Бу кадәр зур эш ачылгач, губерна суды, бөтен Каргалы халкын ерак Якутиягә сөрергә рөхсәт сорап, Петербургтагы сенатка мөрәҗәгать итә.* Ә.Еники. *Дини сәясәт, мөселманнарның көчләп чукындыруга каршы көрәше синод һәм сенат архивларында саклана.* Ф.Ислаев

3) Кайбер дәүләтләрдә парламентның югары палатасы. *Безнең белән*

*бергә Берлин сенаты һәм «Россия халыкларының Берлиндагы дуслары» җәмгыяте җаваплы хезмәткәрләре шундый ук изге гамәлне кылдылар.* Р.Мостафин. *АКШта сенатка һәм вәкилләр палатасына һәр штаттан икешәр сенатор сайлана. Халык санына туры китереп.* Р.Хәкимов

4) Кайбер илләрдә югары муниципаль орган, университет советы һ.б.ш. оешма

**СЕНА́ТОР** *и. лат.* Сенат (*1 – 3 мәгъ.*) әгъзасы. *Чит илләрдә һәр сенаторның төрле мәсьәләләр буенча 20 ләп ярдәмчесе бар.* Т.Миңнуллин. *Мәскәүнең үзе эшләгән Зур театры белән Америкада гастрольдә йөргәндә, атаклы биюче Майя Плисецкаяга Нью-Йорк сенаторы Роберт Кеннединың муеннан гашыйк булуы ачыкланды.* Р.Вәли

**СЕНА́ТОРЛЫК** *и.* Сенатор вазифасы һәм хезмәте

**СЕНБЕРНАР** *и. фр. зоол.* Озын йонлы, эре гәүдәле, көчле эт токымы һәм шундый токымлы эт. *Төркемдәге Полканның ышанычлы дусты Казбек сенбернарлар нәселеннән.* А.Хәсәнов. *Хезмәт хакын айныкын айга җиткерә алмый йөдәгән Әхтәри эт үрчетеп карарга булды. – Сенбернар ал, – дип киңәш итте аңа дусты Хәттаб.* Ф.Зариф

**СЕНСАЦИОН** *с. к.* **сенсацияле**. *Көннәрдән беркөнне иң сенсацион яңалыкны Равил Шәрәфиев алып кайтты.* Т.Миңнуллин. *Эфирдан атаклы биюче Рудольф Нуриевның Франциядә калуы турында сенсацион хәбәр тапшыралар иде.* Р.Батулла. *Икенче көнне дөньяның барлык газеталары Курыновның бу җиңүен «Олимпия уеннарындагы иң сенсацион хәл» дип атый.* А.Гафиятов

**СЕНСА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Берәр көтелмәгән вакыйгага яки хәбәр нәтиҗәсендә туган гадәттән тыш көчле тәэсир, аеруча дулкынландыргыч хәл. *Ләкин, киләчәктә сенсация булырлык берәр зур эш эшләрмен, дигән уй күңелемнән китми.* Г.Мөхәммәтшин. *Ә морза кызы – дворянка Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Заһидә туташның сәхнәгә чыгуы сенсация булды.* Р.Батулла

2) Бик дулкынландыргыч хәлгә, тетрәткеч тәэсиргә сәбәп булган гадәттән тыш вакыйга яки хәбәр, яңалык. *– Әй, – мәйтәм, – язгалыйбыз кайчак, Шуннан гына карап торып та, Сенсация ясап куяр өчен, Кызык хәбәр маташтырып та.* Х.Туфан. *Юк, [Коллинзның] мәкаләсен күрмәдем. Сенсацияне бик ярата, диләр...* А.Тимергалин

**СЕНСА́ЦИЯЛЕ** *с.* Сенсация ясый торган; сенсация тудырырлык, сенсация дәрәҗәсендәге. *Мәскәү газеталары гына ул НЛОлар, «Кар кешеләре» турында сенсацияле мәкаләләр язып яталар.* Ф.Имамов. *Кызык, нинди кеше шундый гаҗәп ачыш ясаган, сенсацияле фаразның авторы кем?* Байрак

**СЕ́НСОР** *и. лат.* 1) Аерым рецептор яки рецепторлы орган (мәс., колак, күз һ.б.)

2) Датчик. *Роботның алгы өлешендә компьютер һәм төрле сенсорлар куелган.* Өмет

3) Берәр приборның, җайланманың үтә сиземле өлеше (гадәттә өслеге). *Сенсорлы экран һәм мәгълүматлар өчен булган махсус файллар бу җайланманың нигезен тәшкил итә.* А.Низамова. *Һәр җирдә урнаштырылган исәпсез-чутсыз камералар да, үзе бер офисны тәшкил иткән сак хезмәте дә, ишектән чыкканда сызгыра торган сенсор тамгасы да чик куя алмый хәйләкәр бурларга.* Ватаным Татарстан

**СЕНСО́Р** *с.* 1) Күрү, ишетү, тою аркылы рецепторлы органнарга тәэсир итә торган. *Биредә медицина кабинеты, бассейн, сенсор һәм музыкаль бүлмәләр бар.* Кызыл таң. *Психологик киеренкелекне бетерү өчен, сенсор көпшә урнаштырылган, вак моториканы үстерергә күпләгән җиһазлар куелган.* Биектау

2) Төрле сигналлар кабул итә торган үтә сиземле өлеше (мәс., экраны, мониторы һ.б.сы) булган. *Тәрбиячеләр өчен интерактив якталар, мультимедиа техникасы, тактиль юллар, сенсор панельләр куелган.* Яңарыш

**СЕНСУАЛИЗМ** *и. лат.* Фәлсәфәдә танып белүнең бердәнбер нигезе һәм чыганагы – тойгы, дигән фикерне алга сөрә торган юнәлеш

**СЕНСУАЛИСТ** *и.* Сенсуализм тарафдары

**СЕНСУАЛЬ** *с. лат. кит.* Тойгыларга, субъектив хисләргә нигезләнгән

**СЕНТА́ВО** *и. лат.* Испан һәм португал телле илләрдә кулланылышта йөри торган акча берәмлеге

**СЕНТЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Үгет-нәсыйхәтле афористик җөмлә, тәгъбир

**СЕНТИМЕНТАЛИЗМ** *и. фр.* 1) XVIII гасырда Европада кешенең рухи дөньясын, мохитен, тормыш шартларын идеаллаштырып һәм шул ук вакытта хискә артык бирелеп сурәтләүгә нигезләнгән әдәби агым. *Г.Исхакый «Теләнче кызы»нда реализм баскычыннан тагын да өскәрәк атлый, «Очрашу, яки Гөлгыйзар» повесте белән кергән романтизм, сентиментализм алымнарыннан да баш тартмый.* Р.Рахман

2) *к.* **сентиментальлек**. *[Сәлимов], Нәфисә килеп керүгә, мәҗлеснең яме китте дип уйлады. Колагына якынрак килеп, Хәбипкә әйтте: – Әйдә, китәбез, монда хәзер сентиментализм башланыр, – диде.* Г.Ибраһимов

**СЕНТИМЕНТАЛИСТ** *и. фр.* 1) Әдәбиятта сентиментализм тарафдары, вәкиле

2) *кит.* Сентиментальлеккә, самими хисләргә бирелүчән кеше. *[Музыка тәэсиреннән] Каратагинның күз төпләрендә яшь тамчылары ялтырап киткәндәй булды. – Николай Сергеевич, Сез сентименталист... – диде Катя.* И.Гази

**СЕНТИМЕНТАЛЬ** *с.* 1) Сентиментализмга нигезләнгән, шуның рухы белән сугарылган (әдәби юнәлеш, әсәр һ.б.ш. тур.). *Әсәрнең уңышы аның сентименталь булуындадыр.* Р.Батулла. *Бүгенге заманда сентименталь сюжетлар, хеппи-энд белән тәмамланган мәхәббәт тарихлары – барысы да телевизион сериалларга күчте.* Идел

2) Эчтәлеге сай яки әһәмиятсез булып, вак, нечкә хисләр белән нык сугарылган, артык төче. *Сентименталь җыр. Сентименталь роман*

3) Сентиментальлеккә, нечкә хисләргә тиз бирелүчән. *Кичер, Һади, син Гөлчәһрәгә артык сентименталь була килдең, яратуың турында син сүз чишмәсе агыза идең.* Р.Батулла. *Мәгърифәтчелек идеяләре, романтик буяулар, кайвакыт елар дәрәҗәгә җиткән сен-*

*тименталь герой... – болар барысы да Г.Кандалый иҗатында бар.* Р.Рахман

**СЕНТИМЕНТАЛЬЛЕК** *и. кит.* Нечкә хисләргә бирелүчәнлек; мөгамәләдә артык ягымлылык, мөлаемлык. *– Бәлки, хискә бирелеп, артык сентиментальлек күрсәткәнмендер? – дип уйлады [Анри].* А.Тимергалин. *Җәүдәт Сөләйманга кызганып язу хас, әмма төчелек, сентиментальлек рәвешендә түгел.* Р.Рахман

**СЕНТЯБРЬ** *и. лат.* Календарь елының тугызынчы, августтан соң килә торган ае. *Сентябрь, октябрь айларында да әле күк җәйге төсен ул кадәр нык үзгәртми.* С.Поварисов. *Былтыр сентябрьдә дә мин дачада яшәп калган идем.* А.Гыйләҗев. *Тәрәзәдән сентябрь кояшының җылы нурлары саркыла.* Р.Зәйдулла

**СЕНЬОР** *и. лат.* 1) *иск.* Көнбатыш Европада җир биләп, шул җирдә чикләнмәгән хакимлек иясе булган феодал; гомумән, башка феодаллардан, вассаллардан өстен торган феодал

2) *исп.* Испан телле илләрдә ир-атларга мөрәҗәгать итү һәм атау сүзе; әфәнде

**СЕНЬО́РА** *и. исп.* Испан телле илләрдә хатын-кызларга мөрәҗәгать итү сүзе; ханым. *Сеньора Мути, журналистлар белән аралашканда, кулындагы дисбе төймәләрен барлап утырды.* Татарстан яшьләре

**СЕНЬОРИ́ТА** *и. исп.* Испан телле илләрдә кияүгә чыкмаган кызларга мөрәҗәгать итү сүзе; туташ. *Бу – әле яңа гына уналтысын тутырган сеньорита Беатриса иде.* Р.Батулла. *– Нихәл, сеньорита! – дип сәлам бирде һәрвакыттагыча шат күңелле, ачык йөзле сәүдәгәр Криг.* Р.Сәгъди

**СЕҢГЕРҮ** *ф.* Эчкә алган һаваны кинәт чыгарып, борын эчен лайлалы сыекчадан чистарту. *– Менә без дә килеп чыктык, – дип кабатлады агай, кесәсеннән керле кульяулыгын чыгарып, пошкырып, борынын сеңгерде.* А.Гыйләҗев. *Китеп барышлый, без малайларга таба борылды һәм, бияләен борын кырыена терәп, ямьсез итеп бер тапкыр борын сеңгерде дә арадан мине танып, яман кычкырды ---.* М.Мәһдиев

**Сеңгереп алу** Тиз генә сеңгерү. *Ләкин тормыш авырлыклары алдында җебеп төшәргә яратмаган Мәгъсүм кинәт авызын зур итеп ачты да каты итеп борынын сеңгереп алды.* Х.Ибраһим

**Сеңгереп кую** Бер тапкыр сеңгерү. *Ул Наиләне кызгануын расларга теләгәндәй, җебегән борынын сеңгереп куйды, аннары: – Бригадирыгыз Мисбах булыр, – дип өстәде.* Ф.Яруллин

**СЕҢДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн.* Сыекча, газ кебек нәрсәне сеңәрлек итеп әйбернең эченә кертү, үткәрү. *Туйганчы, тәмам сеңдереп һәм гөрләвекләр йөгертеп, бөтен дөньяны суга батырып яңгыр явып үткән иде.* Ф.Яхин. *Хәзер ташу да юк инде. Урманнарны кисеп бетерделәр, карны кырларда ук сеңдерәләр, кайдан килсен ул ташу?* Р.Зәйдулла

2) Сеңә торган нәрсәне үз эченә алу; шундый үзлеккә ия булу. *Кар сулары, гөрләвекләр, шәбәеп яуган җәйге яңгырлар Харис абыйның тиресләр белән ашлаган җирен юып кына төшерәләр дә лып итеп Борһан абыйның бакчасына сеңдерәләр.* Н.Кәримова

3) *йөкл. юн. куч.* Күңелдә-хәтердә нык калырлык итеп аңлату, өйрәтү (белемне һ.б.ны). *Мәсьәләнең асылын аның йөрәгенә ышандырырлык итеп сеңдерә алсаң, ул аны башкалар йөрәгенә салырга ашыга.* С.Поварисов. *Син аңа әйт, Туңгак. Баш чабу белән шаярырга ярамаганлыгын үткәзеп, сеңдереп әйт!* Н.Фәттах

4) *куч.* Күңелгә-хәтергә нык алу. *Җитмәсә тагы Әнисә дә моны күңеленә бик җиңел сеңдерде.* М.Шабай. *Ул укыганнарын озак кына вакыт зиһененә сеңдерә алмыйча ятты.* А.Расих. *Тик апасы яңадан берни сорашмады, хәтеренә сеңдерергә җыенган шымчы сыман, утлы күзләре белән баш-аягымны тикшереп чыкты.* А.Гыйләҗев

5) *куч. гади с.* Сугып-кыйнап һ.б.ш. рәвештә тора-кузгала алмаслык итү, егу. *Алып Закир башта [каракларның] пычаклысын сугып сеңдерә һәм бәрәңге базына тибеп төшерә, аннары берәмберәм тегеләрен дә.* Г.Гобәй

**Сеңдерә бару** Берәм-берәм рәттән барысын да эзлекле рәвештә сеңдерү. *Чөнки алар меньшевик, кадет газеталарын җыйнаганда, тегеләрнең һәммә сүзләрен йөрәкләренә сеңдерә баралар.* Ш.Камал. *Ә инде ат чабыштыру, җир эшләре, дөнья көтү сәнгатенә бирелеп китүен Галимҗан бәләкәй чакта ук күреп, үзенә сеңдерә барып үсте.* С.Поварисов

**Сеңдерә килү** Электән үк, күптәннән сеңдерү. *Әтисе тел белән юарга оста, үз карашларын әкренләп кызына сеңдерә килә.* Ф.Яруллин. *Яшияши кеше үзгәрә, мохиткә җайлаша, якыннарының гадәтләрен сеңдерә килә икән.* Т.Галиуллин

**Сеңдерә төшү** Бераз сеңдерү; тагын да күбрәк сеңдерү

**Сеңдереп бетерү** Тәмам сеңдерү; барысын да сеңдерү. *Ә пожарниклар --- халыкны читкә куалар һәм, бик эшлекле кыяфәттә, бармак башы кадәр күмерләрне сүндереп, инде халык әллә кайчан су сеңдереп бетергән урынга шапыр-шопыр су сиптереп йөриләр.* Г.Рәхим

**Сеңдереп калу** Озак вакыт хәтердә сакланырлык итеп сеңдерү. *Бөек дәрья аңа: – Кырлар, болыннар, карурманнар аша узганда, мин башаклар пышылдавын отып алам, чәчәкләр исен, яр буена су эчәргә төшкән ялгыз боланның сагышлы күзләрен хәтеремә сеңдереп калам.* Ф.Әһлиуллина

**Сеңдереп кую** Алдан ук яки тиз арада сеңдерү. *--- моңарчы малай-шалайга үртәргә сәбәп булып кына килгән ике түбәнең дә киләчәктә файдага ярап куячагын күңел почмагына сеңдереп куйды [Әскәр].* А.Гыйләҗев

**Сеңдереп тору** Сөйләү моментында сеңдерү; озак вакыт дәвамында сеңдерү. *Солдатлар аның кычкыруын тыңлап, киеренке йөз белән буйларына сеңдереп тордылар.* Х.Камалов

**СЕҢЕЛ** *и.* 1) Үзеңнән кече кыз туган. *Кайбер очлы күзләргә абый белән сеңелнең үзара мөнәсәбәте бик шикле тоелды.* Н.Фәттах. *Ул, чалгысын атып бәреп, сеңлесе янына очты.* А.Гыйләҗев. *Әлеге Зәйнәб исемле кыз татар мәдәниятендә тирән эз калдырган шәхес – Шиһаб Әхмәровның бертуган сеңлесе булган икән!* Р.Зәйдулла

2) **сеңелем, сеңлем** *форм.* Үзеңнән яшь хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе. *Галимҗан сүзне сорау белән башлады: – Сез моны кайдан алдыгыз, сеңлем?* С.Поварисов. – *Сеңелем, – диде Хөсәен, хисапчы кызга эндәшеп. – Медсестра Шәфикага әйт, өй борынча йөреп чыксын, яралылар байтактыр.* А.Гыйләҗев. *Камәрия тагын каршы төште: – Миңа Гөлнисамнан сер яшерүе бик кыен, сеңелем.* К.Тимбикова

**СЕҢЕЛКӘШ** *и. ирк.* Үзеңнән яшьрәк хатын-кызга иркәләп мөрәҗәгать итү яки атау сүзе. – *Әй сеңелкәш, – диде Хөснетдин, – исең киткән икән!* Ш.Камал. *Бик дефицит чакта «Соната» транзисторын шушы сеңелкәше аркылы алдырдым диган иде [Гайфи].* А.Гыйләҗев. *Сеңелкәшем сөенер инде, дип, үзем дә сөенә-сөенә апаларга киттем.* Г.Мөхәммәтшин

**СЕҢЕР** *и.* Мускулларны сөяккә тоташтыра торган бик тыгыз һәм сыгылма җепселле тукыма. *Шунда ук тире тукыма үрнәкләре: мөгез һәм тояк, сөяк, мускул җепселләре, тире, чәчйон, сеңерләр...* А.Тимергалин. *Соңгы елларда Айсылу шахтада эшләде, саргайган йөзенә күмер тузаны кунды, зур күзләрен җыерчыклар сарды, куллары, тәне сөяк һәм сеңердән генә тора иде.* Ф.Бәйрәмова

**СЕҢЕРЛӘНҮ** *ф.* Сеңер кебек сыгылмалы хәлгә килү

**Сеңерләнеп калу** Нинди дә булса тәэсирдән соң сеңерләнү. *Ул бик ябык, күз чокырлары тирән, куллары чыра кебек корып, сеңерләнеп калган.* Х.Камалов

**Сеңерләнеп тору** Сеңергә охшаш булу

**СЕҢЕРЧӘ** *и.* 1) Нечкә, вак сеңер

2) Яфракта һәм бөҗәк канатында озынча буынтык кебек кечкенә тамыр. *Берөлешлеләр күп кенә билгеләре белән икеөлешлеләрдән җитди аерылып тора: 1) аларда чук тамыр системасы; 2) күбесенең яфраклары гади, сеңерчәләре дугасыман яки параллель урнашкан ---.* Биология. *Дүрт ел буена коелмаучан, --- энә рәвешендәге улаксыман ылыс яфраклары өчәр-өчәр булып ботакка бөҗрасыман урнашкан.* Агулы үсемлекләр

**СЕҢЕШ** *и.* Сеңү процессы һәм үзлеге. *Һәрбер азыкның химик составы һәм ул матдәләрнең сеңеше химик лабораторияләрдә сынаулар аркылы билгеле булган.* А.Расих

**СЕҢЕШҮ** *ф. диал.* Сеңү. *Ун гасыр буе яратып өлгергән, йөрәккә сеңешкән, күңелләребезнең рухына әверелгән гарәп каллиграфиясеннән нигә аерылабыз әле?* С.Поварисов. *Идән уртасында бөрешеп калган малай, башындагы сигез өлгеле кәпәче белән гүя кара эшләпәле кадакка охшап, сайгакка сеңешкән һәм әнисенең тозлы күз яшендә күгәргән иде.* А.Хәлим

**СЕҢҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәнең эченә үтеп, аның күзәнәкләре, кисәкләре арасында таралу (сыеклык, ис һ.б.ш. тур.). *Я, бетте, онытты Фәйрүзә, чәчәк исе сеңгән күлмәген чөеп атты да клубка җыенды.* Н.Гыйматдинова. *Утын яркаларына ияреп кергән кар кисәкләре, кайнар чәйдә эрегән шикәр шакмакларыдай, теләр-теләмәс кенә, агач тәненә сеңеп юкка чыгалар.* М.Кәбиров

2) Кемгәдер бик нык сыену; каты итеп кочаклау; кочагына керү. *Кыз бөтен тәне белән аңа сеңде.* М.Маликова. *Янгураз назларына сусаган тәнем, үзен алдый-алдый, Булат кочагына сеңде.* Р.Габделхакова. *Самат, дерелдәп, әтисенең тынчу кочагына сеңде.* Р.Зәйдулла

3) Берәр өслеккә тыгыз катлам булып яту, керешеп китү. *Рибб Локс яртылаш җиргә сеңгән квартирасына кайтып керде.* А.Тимергалин. *Хәлсезләнгән ир тагын да ныграк ятагына сеңде.* Р.Гыйззәтуллин

4) Чүгү, элекке биеклеген җую, тәбәнәкләнү. *Куркыныч кунак кисәк кенә Вәсиләгә борылды, һәм бер карашыннан түтәй кәнәфигә сеңеп шып булды.* Ф.Гыймалтдинов

5) Нык иелеп, бөгелеп, ятып һ.б.ш. рәвештә күренмәскә тырышып посу, качу. *Малай борчак җиренә сеңгәндәй булды.* К.Тимбикова. *Син, укытучы апа күрмәсен, сорамасын дип, партага сеңеп утырасың, ә ул Кәтүк башы белән, миннән сорагыз, мин беләм дип, кулын күтәрә.* И.Гази. – *Кер, – диде Латыйпов, каушавыннан урындыгына сеңеп.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Хәтергә, күңелгә нык кереп урнашу. *Җирдә кешечә яшәү өчен аларга – тумыштан ук сугышчы булган кыю ирләргә – әледән-әле үләргә һәм яңадан терелергә кирәк иде. Бу аларның канына, миенә сеңгән.* Н.Фәттах. *Үземә тиешле эшләрне бетергәч, дәрес әзерләргә утырган идем, башыма берни сеңмәде.* М.Хуҗин

7) *күч.* Йокыга талу. *Малайларга урын идәнгә җәелде, алар яту белән сеңделәр.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Юкка чыгу; китү; юк булу. *Халыкның аһ-зарлары кайларга сеңде?* М.Мәһдиев

**Сеңә бару** Торган саен ныграк сеңү. *Әйтәсе дә түгел, бу үзе бик гади, үзе аңлаешлы өйрәтүләр малайлар күңеленә көннән-көн ныграк сеңә бара иде.* Ә.Еники. *[Нурия] бөтен тәнендә рәхәт-татлы бер оеганлык сизә, Солтанның җылы кочагына сеңә бара, сеңә бара.* Г.Ахунов

**Сеңә килү** Әкренләп күптәннән бирле сеңү. *Әнисенең ул гадәте Рәйханага бала чактан ук сеңә килде.* Р.Ишморатова

**Сеңә төшү** Бераз сеңү; тагын да ныграк сеңү. *Текә яр тәбәнәкләнгән, җиргә сеңә төшкән.* Ф.Бәйрәмова

**Сеңеп бару** Рәттән барысы да сеңү. *Салих әфәндененең бөтен әйткәннәрен аңлавы җиңел иде, һәр әйткәне, ничектер, үзеннән-үзе күңелгә кереп, хәтергә сеңеп бара иде.* Ә.Еники. *Сөмбеләнең алмаз яшьләре шунда эзсез сеңеп бара...* А.Гыйләҗев

**Сеңеп бетү** Тәмам сеңү, нык сеңү. *РТЯның бер тулай торагы Гоголь урамында тыштан бик матур, ләкин эченә карболка исе сеңеп беткән ак йортта иде.* Ә.Еники. *Әнә, янтаеп, җиргә сеңеп беткән өй.* А.Тимергалин

**Сеңеп калу** Үз вакытында сеңү; ниндидер вакыйгадан соң сеңү. *Әтисенең туган җире аның аңына мәңге җәй, мәңге кояш, яшеллек һәм тынычлык хакимлек иткән сихри ил булып сеңеп калды.* Н.Фәттах. *Кадриясенең кичә тырышып-тырышып сөйләгән*

*сүзләре, чыннан да, хәтергә сеңеп калмаган иде ---.* А.Гыйләҗев

**Сеңеп китү** Кинәт сеңү. *Салон-ресторанда ул көлгәндә, теплоход суга сеңеп киткән сыман була иде.* М.Мәһдиев

**Сеңеп тору** Даими сеңү, озак вакыт дәвамында сеңү; сеңгән булу; күпмедер вакытка сеңү. *Сезнең шигырьләрегез йөрәккә сеңеп тора, алар, улагын тутырган чишмә булып, күңелгә агыла.* М.Хуҗин. *--- нәни чебиләр, нәни бәпкәләре генә түгел, дөнья күргән тәҗрибәле тавыклар да бер мизгелгә һуштан язарга җитеп, җиргә сеңеп тордылар.* Ф.Шәфигуллин

**СЕПАРАТ** I *и. лат.* Сөт аерту аппараты. *Олы яктан сепарат тавышы ишетелә, шул тавышка кушылып, аяк очында рәхәтләнеп йоклап яткан мәче мырлый.* Х.Сарьян. *Бәләкәй чакта ул сепаратны күп әйләндерергә туры килде.* А.Гыйльми

**СЕПАРАТ** II *с. лат. сәяси* Бөтәннәрдән аерылып, аерым эшләнә торган. *Сепарат килешү. Сепарат сөйләшүләр алып бару*

**СЕПАРАТИВ** *с. лат. кит.* Сепаратизм белән сугарылган. *Сепаратив чыгышлар. Сепаратив фикерләр*

**СЕПАРАТИЗМ** *и. лат. сәяси* Аерылып, бүленеп чыгуга, аерымлану омтылышына нигезләнгән сәясәт. *Без берниди сепаратизм белән дә шөгыльләнмибез, Россия законнары кушкан микъдарда суверен булып, дәүләт булып, бергә Россиянең киләчәген кайгырту өчен яшибез.* Т.Миңнуллин. *Ә республика һәм өлкәләргә сепаратизм ярлыгы тагып, сәламәт тамырларына балта чабуны мин гомумән аңламыйм.* Р.Вәлиев

**СЕПАРАТИСТ** *и. сәяси* Сепаратизм тарафдары. *Әллә нинди кушаматлар таксалар да, без террорист та, ваһһаби да, сепаратист та түгел.* Т.Миңнуллин. *Хәтта тыныч сепаратист өндәмәләрнең дә экстремизм дип бәяләнүенә Конституциядә анык язылмау сәбәпче, диелә.* Н.Акмал

**СЕПАРА́ТОР** *и. лат.* 1) *тех.* Бер матдәне яки матдәнең кайбер өлешләрен икенчесеннән чистарта, аера торган җиһаз яки аппарат. *Төргәкләр тискәре һәм уңай кисәкләрдән араларына сепараторлар куеп җыелалар.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Без Җәүдәт белән суыткыч рәвешендәге, гади судан җиңел суны аерып ала торган «сепаратор» проекты эшләдек.* Татарстан яшьләре

2) *к.* **сепарат**. *Байтираккә беренче сепараторны ул алып кайткан.* Г.Бәширов. *Кайбер очрашуларда мотоцикл, тегү, кер юу машиналары, хатын-кызларга кышкы күн итекләр, сепаратор кебек нәрсәләр дә сорадылар.* Ф.Садриев. *Төрле маркадагы сәгатьләр, сепаратор кебек көнкүреш техникасын ремонтлап бирүне сорап та еш мөрәҗәгать итәләр аңа.* Т.Нәҗмиев

**СЕПАРАТЧЫ** *и.* 1) Сепаратны карап-төзәтеп торучы

2) Сөт җитештерү тармакларында сепаратта эшләүче, сөт аертучы эшче. *Шуңа күрә Камайның машина эчендә үзалдына сөйләнгән кебек авызын кыймылдатып, һаман чыкмыйча утыруын күргән сепаратчы Тәслимә моны мафия йоласын башкарудыр инде дип юраган.* Җ.Юныс

**СЕ́ПСИС** *и. гр. мед.* Авыру барлыкка китерүче микробларның канга кереп таралуы нәтиҗәсендә организмның гомуми агулану күренеше, хәле. *Моның сәбәбе: сепсис эчке әгъзаларга зыян китерә, алар үз функцияләрен башкара алмый башлый.* Ватаным Татарстан. *Инфекция канга киткән, сепсис башланды.* Татарстан яшьләре

**СЕПТЕТ** *и. лат.* 1) *муз.* Җиде башкаручыдан, җырчыдан яки уйнаучыдан төзелгән музыкаль ансамбль, төркем

2) *муз.* Мөстәкыйль партияле җиде уен коралы яки җиде тавыш өчен язылган музыкаль әсәр

3) *әд.* Җиде юллык шигырь

**СЕ́ПТИК** *с.* Сепсиска мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Септик ангина бер атна чамасы дәвам итә: тамак туктаусыз шешә, шуннан соң олы кан тамыры шартлый да, авыз-борыннан кан китә, ул агып беткәч, йөрәк тибүдән туктый...* Гасырлар авазы. *Ләкин бу бөртекләр агулы була, ул септик ангина дигән авыру китереп чыгара.* Ватаным Татарстан

**СЕР** *и. гар.* 1) Әлегә ачылмаган, танып беленмәгән үзлек, сыйфат һ.б.ш. *Биясенең серен иясе белер.* Мәкаль. *Әллә нинди тылсым, ымсындыргыч сер бар иде ул күзләрдә.* Р.Зәйдулла

2) Башкаларга белдерергә ярамый торган яшерен мәгълүмат, хәбәр, яңалык һ.б.ш. *Исәнтәйнең каган белән шундый кыю, иркен сөйләшүе, җитмәсә, аларның икесенең генә ниндидер уртак серләре булуы --- Туңгак алыпның чиктән тыш эчен пошырды.* Н.Фәттах. *Хәзер алар гади юлчы, авылдашлар гына түгел, аларның икесенә дә бик кадерле, уртак серләре бар иде.* А.Гыйләҗев. *Алда – ике бәла. Берсе – полковниктан сер алу. Икенчесе – Алмабикә мәсьәләсе.* С.Поварисов

3) *тарт. форм.* Берәр нәрсәнең төп эчтәлеге, асылы, әһәмияте. *Гөлсинә башлаган хәрәкәтнең дә серенә төшендем.* Р.Ишморат. *Ничә ел инде шул станокта эшлим, ләкин серләренә һаман төшенеп беткән юк әле.* К.Латыйпов. *Минем иркәм төзүче – Бетон серен белүче.* Х.Туфан

4) Ачыкланмаган, билгесез сәбәп. *Уңышының сере тырыш булуында аның.* И.Нуруллин

◊ **Сер бирмәү** Кайгы-борчуны, авырлыкны һ.б.ны сиздермәскә тырышу, сынатмау. **Серен алу** Кеше үзе белгертергә теләмәгәнне белү, шуны сөйләттерү. *Хифасулла карт аның серен алырга кергән. Күренеп тора.* А.Гыйләҗев. **Сер капчыгы** Яшерен мәгълүматны, кеше белергә тиеш булмаганны саклаучы турында. *Алладан бернәрсәне дә яшереп булмаган кебек, бөек затларның да кылган эшен сер капчыгында саклап тору һич мөмкин түгел.* С.Поварисов. **Серләр килешү** Кем беләндер карашлар, зәвыклар, теләкләр, фикерләр туры килү, уртак булу; якын булу, дус булу. *Аларның икесенең бер-берсе белән серләре бик килешә.* Г.Камал. **Сер сынатмау** *к.* **сер бирмәү**. *Ялгыз булсаң, йөрәгең ярылыр иде, ә өчәү булгач, сер сынатмыйбыз инде.* Ә.Еники. *Хөсәенгә мондый тәнбиһ авыр тоелды, ләкин ул сер сынатмады, кашларын җыергалап булса да, бу чәнечкеле тигәнәкне йотты.* А.Расих.

*– Мондый чакта ятып торган ирне син ир дип әйтерсеңме соң? – диде Туңгак алып, сер сынатасы килмичә.* Н.Фәттах. **Сер сыю** Кемгә дә булса ышанып, сер сөйли алу. *Заманында безнең дә сер сыя иде, бер-беребезне бер дә чит итми идек.* А.Гыйләҗев. *Сер сыярлык бер кешем генә дә юк.* К.Тимбикова. *Сез инде сер сыймаслык кешеләр түгел, соңыннан мин әйткәннәрне кемгәдер сөйләрсез дип тә уйламыйм.* Г.Галиева

**СЕРАДЕ́ЛЛА** *и. исп.-порт. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күбесенчә тропикларда һәм субтропикларда үсә, мал азыгы буларак файдаланыла торган үләнчел үсемлек; кош тәпие

**СЕРӘЮ** *ф.* Күңелсез тәэсир калдырыр дәрәҗәдә төз катып, сәер тураеп утыру, тору, урнашу. *Менә мин серәеп ишек төбе саклыйм.* Х.Сарьян. *Юрганнан серәеп чыгып торган аякларымны күреп, [нәнәй] кеткелдәп көлә: – Үстең инде, үстең. Сөбханалла!* М.Кәбиров

**Серәеп калу** Берәр тәэсирдән соң серәю. *Аннары... Ак мунчамның серәеп калган кап-кара моржасы янында Мырыкбаем белән кара-каршы утырып аңлашканым яхшы хәтеремдә.* Г.Сабитов

**Серәеп тору** Күпмедер вакыт, гел яки хәзерге моментта серәйгән хәлдә булу. *Авылларның салам башлы өйләре арасыннан өскә чыгып, серәеп торган кое баганалары [күзгә бәрелде].* М.Гафури. *Лида белән ике арада һәрвакыт шушы бәндә серәеп торачак!..* А.Гыйләҗев. *Күктә йолдызлар тагын да яктырак яна, һәр йолдыз аерым-аерым серәеп тора.* Ч.Айтматов

**СЕРБ** *и. гр.* Башлыча Сербия республикасында яшәгән, көньяк славян группасына караган телдә сөйләшкән халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Шәһәрнең ак чехлардан, словак, серб, акгвардиячеләрдән бөтенләй азат ителүенең икенче көне...* Ә.Мушинский. *Араларында үзе гармунда уйнап, үзе җырлаучы серб милләтеннән дә берәү бар бит хәтта.* Ф.Гыйльманов

**СЕ́РБИЯЛЕ** *и.* Сербиядә яшәүче кеше. *Командадан китүчеләр исемлегендә Андрей Фёдоров, сербияле Саво Милошевич һәм Андрей Кобенко тора.* Татарстан яшьләре

**СЕРВАЛ** *и. порт. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан Африкада яшәүче, куаклар арасында тереклек итүче затлы мехлы җәнлек

**СЕРВАНТ** *и. лат.* Савыт-саба һ.б.ш.ларны саклый торган, гадәттә өске өлешендәге ишекләре пыяла шкаф, буфет. *Инде бритва гөҗли башлауга ук, [Идриснең] күзе сервант өстендәге көзгегә төшә.* А.Гыйләҗев. *Мин аны, иң якын дуслар белән өстәл янында утырганда гына, сервинттан чыгарам.* М.Мәһдиев

**СЕРВЕЛАТ** *и. нем.* Ысланган казылык төре. *Буфетта кибет бәясеннән ваклап коньяк саталар икән, закускага – туралган лимон, сыр, сервелат, шоколад һ.б.* Татарстан яшьләре

**СЕ́РВЕР** *и. ингл. информ.* 1) Компьютерларда мәгълүмат ресурслары белән идарә итә торган программа. *Чатта сүгенүчеләргә, ызгыш «авторлары»на сервер администраторы җәза бирә: я персонажын «төрмәгә утырта», я вакытлыча уеннан читләштерә.* Татарстан яшьләре

2) Билгеле бер сервис функцияләрен үти торган компьютер яки компьютер җайланмасы. *Беренчесендә – сервер, иң яңа технологик җиһазлар, икенчесендә – абонент техникасын тестлау лабораториясе.* Мәдәни җомга

**СЕРВИЗ** *и. лат.* Бер төрле стильдә сәнгатьчә эшләнгән, билгеле кеше санына исәпләнгән савыт-саба җыелмасы. *Җайлырак та егылырга була иде, кулымдагы кыйммәтле чәй сервизын саклыйм дип, үземне сакламаганмын.* Г.Галиева. *--- ә укытучы апага чәй сервизы бүләк итәргә уйлыйбыз.* Г.Мөхәммәтшин

**СЕ́РВИС** *и. лат.* 1) Халыкка көнкүрешнең төрле тармакларында күрсәтелгән хезмәтләр. *Бу, әлбәттә, ядкәрлекнең уңышлы эшләвен, туристлар, кунаклар һәм, гомумән, ядкәрлеккә килүчеләр өчен күркәм генә мәдәни сервис күрсәтү була алыр иде.* Р.Вәлиев. *Менә ичмасам сервис дисәң дә була!..* Р.Гаязетдин

2) Халыкка хезмәт күрсәтә торган предприятие. *Машинаны сервиска илтү*

3) *информ.* Билгеле хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирә торган техник чара. *Исегезгә төшерәбез: сәламәтлек саклау өлкәсен мәгълүматлаштыру программасы кысаларында киләсе елдан «Пациентның шәхси кабинеты» дип аталган яңа электрон сервис эшли башлаячак.* Шәһри Казан

**СЕРДӘШ** *и.* Серне уртаклашучы дус. *Сердәш миңа җилсез көннәрдә дә Үкси торган моңлы камышлар.* Х.Туфан. *Бүлмәдәшләре арасыннан сердәш табылмады егеткә, кырык кеше арасында ул япа-ялгыз иде.* А.Гыйләҗев. *Эрнест үз улына ышана иде, аның белән тиң итеп сөйләшә, сердәш булырга тырыша.* Р.Зәйдулла

**СЕРДӘШЛЕК** *и.* Сердәш булу; якын дуслык. *Соңгы елларда иҗаттагы дуслыктан тыш, чын күңелдән булган шәхси дуслык һәм сердәшлек белән бәйләнгән дустыңны – мине – бу карар аеруча шатландырды.* М.Җәлил. *Бу «мин сез наяннарны беләм бит» дигән сыман хәйләкәр, шуның белән бергә дусларча сердәшлекне белгертә торган караш иде.* Ә.Фәйзи

**СЕРДӘШЧЕ** *и. ялг. к.* **сердәш**. *Әле кайчан гына кара дошман булып күренгән Гайния хәзер инде, ире үлгәннән соң, аның [Маһибәдәрнең] иң якын дусты, сердәшчесе булыр кебек тоела.* Ф.Хөсни. *Мәрьям [Шакирга] дус иде шул, сердәшче, якын киңәшче иде.* Ә.Еники

**СЕРДОЛИК** *и. гр. мин.* Кызгылт алсу яки кызгылт сары төстәге металл; халцедонның бер төре. *Сердолик, гранат ташлары ошый миңа, ювелир кибетенә керсәм, шулар тирәсеннән алып китәм димә.* Р.Вәлиева. *Аның сердолик ташыннан ясалган балдагы булган.* Ватаным Татарстан

**СЕРЕНА́ДА** *и. ит.* 1) *әд.* Көнбатыш Европада берәүне, гадәттә сөйгән кызны сәламләп җырлана торган хөрмәтләү, мактау җыры. *Син җирдә, кулыңда гитара. Серенада җырлыйсың.* А.Гыйләҗев. *Һәр үлән кыягы, һәр чәчәк, һәр яфрак сискәнеп уянды, киң сулыш алды, иртәнге серенадага үзенең җыры белән кушылды.* Ф.Әһлиуллина

2) *муз.* Лирик эчтәлекле әсәрнең бер төре. *Серенада җырлаучы егетләр, мантилья салган кызлар, кызыллы-каралы плащлар кигән тореадорлар*

*причалда юк иде.* М.Мәһдиев. *Кошлар җыры – иртәнге серенада.* Р.Низамиев

**СЕРЖАНТ** *и. лат.* 1) Армиядә яки полициядә хезмәт итүче кече команда составы вәкилләренә бирелә торган звание, дәрәҗә. *Екатерина Павловна Газинурны сержант исеме белән тәбрикләде, киләчәктә сине офицер итеп күрергә насыйп булсын, диде.* Г.Әпсәләмов

2) Шул званиедәге кеше. *Хәзерге вакытта Ибраһим Янгуразов – отставкадагы полковник, Уфада тора, ә мин бары сержант кына.* Ә.Еники. *– Ә мин профессорларны акыллы кешегә чутлап йөри идем, – диде тәбәнәк буйлы бер сержант.* Р.Зәйдулла

**СЕРЖАНТЛЫК** *и.* 1) Сержант званиесе, дәрәҗәсе. *Динар, алты ай дәвамында Свердловск өлкәсе Порошино бистәсендә хезмәт итеп, сержантлык дәрәҗәсенә күтәрелә.* Безнең гәҗит

2) Сержант вазифалары һәм хезмәте

**СЕРИАЛ** *и. ингл.* 1) Берничә сюжет линиясе булган күпсерияле фильм. *Бу көннәрдә күпчелек халык, мәш килеп, бер сериясен дә калдырмыйча, күрәзәче Ванга турында сериал карый.* Шәһри Казан. *Көн дә берәр-икешәр бүлек укыйм, бу үзенә күрә сериал булган икән, дип елмаеп куям хәзер.* Кызыл таң

2) Рәсем, театр, кино һ.б. сәнгатьләрдә бербөтенне тәшкил иткән әсәрләр

**СЕ́РИЯ** *и. лат.* 1) Бер үк билгеләнештәге, жанрдагы, тематикадагы охшаш нәрсәләр төркеме. *«Шәрыкның югалган культуралары» дигән сериядән бөтен китапларны җыеп барам.* А.Гыйләҗев. *И әни, әни. «Төн» сериясеннән ясалган рәсемнәр алар.* Н.Гыйматдинова

2) *тех.* Бер стандартка туры китереп эшләп чыгарылган деталь, машина һ.б.ш.лар. *Югары ешлык триодларын да иң соңгы сериядәгеләр белән алмаштырдым.* А.Тимергалин. *Бөтенләй таныш булмаган бу егетнең машина номерындагы серия хәрефләре «КЕУ» була, шуны абайлап алган Илдар: «Карале, кияү килгән бит!» – дип көлә, һәм егет, вакыт узу белән, чынлап та, кияү булып китә.* Кызыл таң

3) Кыйммәтле кәгазьләрнең (акча, облигация һ.б.ларның) бер үк цифрлар яки хәрефләр белән билгеләнгән разрядды, категориясе. *Кайбер ялган акчаларда серия номерлары гадәттән тыш ачык төс белән язылган.* Шәһри Казан. *Лотереяның серия номеры*

4) Зур кинофильмның бер сеанс дәвамында күрсәтелә торган бер кисәге, өлеше. *Хәтерегездәме, әле беренче серия башында ук колхоз председателе Чубарь атлы бер агай сугыш булып үткән арыш кырында, янган танк янында бер винтовка табып ала.* А.Хәсәнов

5) Бер максат белән эшләнгән эшгамәлләрнең эзлекле рәте. *Тулы бер серия талау очрагын яшүсмер кылганын белгәч, үзебез дә аптырап калдык.* Безнең гәҗит

**СЕ́РИЯЛӘП** *рәв.* Серия (*2 мәгъ.*) нигезендә. *Очкыч бәясе сериялəп җитештерелә торганына караганда ике тапкырга артыграк, диде ул.* Ватаным Татарстан. *«Балачак әдипләре» кебек исемнәр астында сериялəп чыгарыла торган китапларны мәктәп китапханәләренә таратуны оештырырга кирәк.* Сабантуй

**СЕ́РИЯЛЕ** *с.* 1) Бер сериядә эшләнгән. *Әмма гадәти серияле номерлы машина хуҗаларына борчылырга кирәкми: бу номерлар гамәлдә кала.* Татарстан яшьләре

2) Билгеле сандагы сериядән торган, күп серияле булган

3) Нәрсәне дә булса бер төрле алымнар белән эшли торган. *Әгәр дә серияле үтерүчебез чыннан да Фидан Чемодан һәм ул агачлар арасында чираттагы корбанын сагалап торган икән, шаһит китәргә тиеш булган зат син искә алган микрорайонда яшәп ятырга тиеш.* Ф.Бәллүр

**СЕРКӘ** I *и. бот.* Орлыклы үсемлек серкәчендә җитлегеп тарала торган төкчәләрнең берсе, аталык күзәнәге. *Аның янәшәсендә сарут һәм кылган кыякларыннан, үлән төкләреннән талгын искән җилдә аксыл серкәләр оча.* А.Хәлим. *Билгеле булганча, күп кенә авыл хуҗалыгы культуралары, нектар җыйганда, бер үсемлектән икенчесенә серкәләр күчерә торган бөҗәкләр аларның чәчәкләренә кунган очракта гына, мул уңыш бирә алалар.* Умартачыга ярдәмлек

◊ **Серкәсе су күтәрмәү** Тәнкыйтьшелтәне яратмау, үпкәчел булу. *Аның артыннан кече капка шапылдап ябылгач, Рәүф: – Серкәсе су күтәрми шәһәр малаеның, – диде.* А.Тимергалин. *Мөнзиргә шаяртып кына әйткән идем мин «Ялкау Хәмидә» дип, Рәгъди абзый. Су күтәрми икән серкәсе.* Ф.Шәфигуллин. *Картайган шул, сак булыгыз: Серкәсе су күтәрми.* Мөҗәһит

**СЕРКӘ** II *и.* Бет, кандала кебек вак бөҗәкнең озынча күкәе. *Чат ябышкан урындыкка – Серкәмени. Биеклекне сөя үзе – Күркәмени. Андый бәндә егылудан Куркамыни.* Мөҗәһит

**СЕРКӘ** III *и. фар.* Аш тәмләтү, маринадлау, консервлауда файдаланыла торган кискен исле, әче төссез сыекча. *Театр училищесында булып узган хәлне кыз бик авыр кичерде: ак серкә шешәсен тотып, тәрәзәгә шомлы карап, ул байтак кичләрен уздырды, төннәрен җылап чыкты, ябыкты, киптекорышты.* А.Гыйләҗев. *Мәсәлән, бу борщта бәрәңгедән тыш тагын чөгендер, кәбестә, кишер, ит, --- вак кына итеп туралган яшел петрушка, серкә, икмәк квасы, --- хуш исле дәфнә яфрагы, тоз, су һәм башка ризыклар бар.* Г.Мөхәммәтшин

**СЕРКӘБАШ** *и. бот.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык дару һәм декоратив үсемлек; *русчасы:* **пыльцеголовник**

**СЕРКӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* Үсемлектә: серкәне (I) аналык органнарына күчерү. *Тагын шунысын да онытмаска кирәк: ел саен ничәшәр мең сум табыш бирә, күпме игенне серкәләндерә кортлар!* Г.Бәширов

**СЕРКӘЛӘНҮ** *ф. бот.* Үсемлектә: җимешлеккә (аналык органына) серкә (I) күчү. *...Арыш серкәләнгән көннәр иде.* М.Мәһдиев. *Чәчәк озак кына дәшми торды да нәзек кенә тавыш белән: «Син бал кортларын куасың, алар килмәгәч, мин серкәләнә алмыйм».* Г.Сабитов. *Ырымбур далаларыннан Өязе үзәне буйлап күтәрелгән хуш исле исерткеч әрем исе, серкәләнгән арыш исләре кушыла Сәгъдәт тавышына.* А.Хәлим

**Серкәләнә башлау** Серкәләнергә тотыну. *Агачлар, үсемлекләр серкәләнә*

*башлаган чор алар өчен газапка тиң.* Ватаным Татарстан

**Серкәләнеп бетү** Серкәләнүдән туктау

**Серкәләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә, тәмам серкәләнү

**СЕРКӘЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Серкәләрен тарату, кою; серкә очыру. *Җил чыккан вакытта, ата чәчәкләрнең серкәләре күрше агачның ана чәчәкләрен серкәли.* Табигать белеме

2) Нәрсәгә дә булса серкәләр ягу, серкәләрдән тап калдыру. *Исләрен тойыйм дип иснәсәң, аклы-көмеш серкәләре борын очында гына серкәли.* А.Хәлим

**Серкәли башлау** Серкәләргә тотыну

**СЕРКӘЛӘ́Ү** II *ф.* Чәч бөртекләре арасында бет серкәләре барлыкка килү

**Серкәләп тору** Әледән-әле яки хәзер серкәләү

**СЕРКӘЛЕ** I *с.* Серкәсе (I), серкәләре булган. *Их, ул чәчәкләрнең зифа көязлеге, иркә сылулыгы, үзләренә генә хас серкәле һәм тиз уалучан матурлыгы!* А.Хәлим

**СЕРКӘЛЕ** II *с.* Өстендә яки эчендә серкәләре (II) булган, серкәләгән (баш, чәч һ.б. тур.)

**СЕРКӘЛЕ** III *с.* 1) Серкә (III) салынган, кушылган (ризык тур.)

2) Серкә салып куелган, эчендә серкә булган (шешә һ.б.ш. савыт тур.). *Тәрәзәне ачып, серкәле шешәсен урамга атты да кайгысын эченә йотты [Нурдидә].* А.Гыйләҗев. *Таймасның калайны серкәле су белән юып йөргәнен исенә төшереп: «Кара син аны, серкәне бер дә күтәрми икән», – дип уйлады.* А.Тимергалин

**СЕРКӘЛЕК** *и. бот.* Серкәчнең өске, серкәле өлеше; *русчасы:* **пыльник**. *Серкәлектә бик вак бөртекчәләр – серкәләр була.* Ботаника

**СЕРКӘЧ** *и. бот.* Чәчәкнең серкәлектән һәм аның җепсел сыман сабакчыгыннан гыйбарәт органы; *русчасы:* **тычинка**. *Зирек агачында быелтыр көздән әзер булып калган алкаларда тәңкәсыман серкәч күренде.* М.Максуд

**СЕРЛӘШҮ** *ф.* Башкалардан яшереп, ишеттермичә, үзара гына сөйләшү. *Кил әле, кун әле, Кулыма, Күбәләк! Серләшик әле без Бүген дә бергәләп.* Х.Туфан. *Йу белән алар серләшкән булганнар.* Н.Фәттах

**Серләшә башлау** Серләшергә керешү. *Кара син аларны, шул арада серләшә дә башладылар.* Г.Каюмов. *Ул ара булмый, кызлар үз яңалыкларын, үз хәлләрен генә серләшә башлый.* М.Вәлиев

**Серләшә бирү** Бернигә дә карамый серләшүне дәвам итү. *Ә зираттагы каеннар, берни дә булмагандай, купшы яфракларын кыштырдатып серләшә бирделәр.* М.Мәһдиев

**Серләшеп алу** Аз гына серләшү. *Утыз биш ел буе аңлашып типкән йөрәкләр бер-берсенә сыенышып серләшеп алды: «Аңлыйм бит, картым, хәлеңне аңлыйм».* А.Вергазов. *Менә алар берберсе белән пышын-пышын гына серләшеп алдылар да, салам өстенә чүгәләп, бер мәлгә тын калдылар.* Х.Ибраһим

**Серләшеп тору** Сөйләү моментында серләшү; һәрдаим серләшү. *Беркөнне шулай җил белән, дулкыннар һәм акчарлаклар белән серләшеп торганда, причал янындагы яссы палубалы баржаплашкоут өстендә ашыгып әрле-бирле йөргән брезент киемле кешеләрне күреп алды ул.* М.Маликова. *Читтән карaганда, алар серләшеп торган кешеләрне хәтерләтәләр.* Г.Гыйльманов

**СЕРЛЕ** *с.* **1**. 1) Үзлекләре әлегә ачылмаган, танып беленмәгән. *Болар барысы да Канәгать өчен серле китап укуга тиң иде.* А.Хәлим. *Әлбәттә, бу серле чәчәк шытсын өчен, кеше күңелен ниндидер шифалы сулар сугарып торырга тиештер, мөгаен...* Р.Зәйдулла

2) Кешегә белдерергә ярамаган, яшерен. *Сафия аның [егетнең] хәрәкәте, сүзләреннән аның белән Лутов арасында ниндидер серле мөнәсәбәт барлыгын сизенеп, шуны белергә тели.* Г.Нигъмәти

3) Шомлы, шикле. *Җир казучылар янында Галләм белән Архиповның сөйләшеп торулары аңа [Садыйкка] томанлы һәм йөрәк әрнеткеч серле булып күренә.* Ш.Камал

4) Сәер; аңлавы-төшенүе кыен булган; башкалардан аерылып торган. *Алмабикә дә бик чибәр иде. Уртача буй. --- Ак калфак. Муенса. Серле елмаю. Килешле йөрү.* С.Поварисов. *Ике серле карчыкның Санияләрдә яши башлавын Хәлимнең югалып йөрүе, Майяның үлеме белән бәйләүчеләр дә булды.* Г.Гыйльманов

5) Хисле һәм шигърияtle. *Тау буена бар син язның Серле, айлы кичендә.* Ф.Кәрим. *Зәңгәр күзләр елмаялар – Серле матурлык анда.* Ә.Ерикәй

**2.** *рәв. мәгъ.* Бертөрле киная белән; башкача; хис белән. *– Миңа кирәк имәс, – диде Исәнтәй серле пышылдап. – Барысын да сиңа...* Н.Фәттах. *Ишегалдына чыгу белән бабай, бакча башындагы мунчага таба серле генә ым кагып, эче тулып ашкан куанычын карчыгына сиздерәсе итте.* Г.Галиева

**СЕРЛЕЛӘНҮ** *ф.* Серлегә әйләнү; аңлашылмас, сәер хәлгә килү. *Бер караганда, ул элекке Галия, бер класста укып йөргән иптәш кыз булса, икенче күргәндә, бөтенләй ят кешегә әйләнә, серлеләнә, ерагая.* Ф.Яруллин

**Серлеләнә бару** Торган саен серлеләнү

**Серлеләнә төшү** Бераз серлеләнү; тагын да серлеләнү. *Җәмил биргән төргәк сере әбәт вакытында тагын да серлеләнә төште.* Г.Гобәй

**Серлеләнеп китү** Соңгы араларда серлеләнү

**СЕРЛЕЛЕК** *и.* Серле булу сыйфаты, хәле; серле нәрсәгә яки кешегә хас сыйфатлар. *Анасы камның изгелеге, серлелеге алдында аның тәмам зиһене томаланды.* Н.Фәттах. *Кунак, тамак төбе белән генә көлеп, төсенә серлелек чыгарды.* А.Гыйләҗев. *Әмма күзләрендәге элеккеге наз бераз гына кимегән, күзләр тоныкланып киткән, карашларда ниндидер серлелек, яшерен сагыш бар.* М.Мәһдиев

**СЕРПАНТИН** *и. лат.* 1) Зур кичә, бал, маскарад һ.б.ш.ларда катнашучылар арасына атыла яки бизәү өчен эленә торган, ялтыравык төсле кәгазьләрдән ясалган озын тасма төргәге. *Мөршидә белән Мәрьям, бер-берсен бүлә-бүлә, кабаланып тезә башладылар: – Ике бүлектән зур концерт! – Соңыннан милли уеннар, сәгать өчкә кадәр танцы! – Конфетти белән серпантиннар!* Ә.Еники

2) Таулардан әйләнеп-әйләнеп, текә борылышлар ясап уза торган юл. *Бу*

*серпантинны тәҗрибәле машина йөртүчеләр дә яратмый.* Казан утлары

**СЕРТИФИКАТ** *и. фр.* 1) Билгеле бер фактны раслый торган документ (мәс., белем дәрәҗәсе, товар сыйфаты һ.б.). *Мәктәп үзенең белем сертификатларын булдыра һәм шуның нигезендә белем таныклыклары бирә.* И.Әмирхан. *Аннары мине, сертификатым булмаган килеш, башка эшкә дә ала алмаячаклар инде.* И.Кәримов. *Сез курсларга йөрүчеләргә диплом яки сертификат бирәсез, димәк?* Татарстан яшьләре

2) Билгеле күләмдәге акчаны алыштыра алырлык, ягъни күрсәтелгән суммага нәрсә дә булса алу, файдалану мөмкинлеге бирә торган документ. *Әйтик, иң беренче көнне үк Мәскәү мэры урынбасары коляскалы инвалид баскетболчыларга бүләк сертификатлары таратты.* Э.Фатыйхова. *Юк, ветеранга торак өчен бары сертификат кына бирелә, акча исә йортны төзегән төзү оешмасына турыдан-туры күчерелә.* Ватаным Татарстан

3) *фин.* Махсус заёмнарның облигациясе; дәүләт органнарының заём буенча финанс ягыннан җаваплылыгы

**СЕРТИФИКАТЛА́У** I *и. к.* **сертификация**. *Сөт продукциясен сертификатлау буенча белгеч Наталья Агеева Башкортстанда кымыз җитештерүдә сыйфатка тиешле игътибар бирелмәвен ассызыклады.* Кызыл таң

**СЕРТИФИКАТЛА́У** II *ф.* Товарның һ.б. сыйфаты гомумкабул ителгән стандартларга туры килүе хакында белешмә алу (бирү). *Ел ахырына кадәр җитештерелгән техник җайланмаларны сертификатларга кирәк.* Ватаным Татарстан

**СЕРТИФИКАТЛАШТЫРУ** I *и. к.* **сертификация.** *Ирекле сертификатлаштыруның максаты – базар мөнәсәбәтләре шартларында уңышлы эшчәнлекне тәэмин итү.* Ышаныч яулыйсың килсә. *Пиротехник эшләнмәләр, һичшиксез, сертификатлаштыру узарга тиеш, ә аларны кулланыр алдыннан фейерверкны кайсы урында җибәрәчәгегезне ачыклагыз.* Дуслык

**СЕРТИФИКАТЛАШТЫРУ** II *ф.* Сертификация үткәрү. *Татарстанда бүгенгә «Татнефть – АЗС Центр», «Күзкәй», «Автодорстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләре һәм «Татнефтепродукт» холдинг компаниясе» ААҖ карамагындагы 65 станция сертификатлаштырылган.* Шәһри Казан

**СЕРТИФИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *икът.* Товарның сыйфаты гомумкабул ителгән стандартларга туры килүе хакындагы мәгълүматны раслау эше. *Бу сүздән рус теле җирлегендә «товарларның сыйфат яраклылыгын билгеләү» мәгънәле яңа сертификация сүзе дә ясалды: октябрьдән башлап илгә кертелә торган товарларга мәҗбүри сертификация үткәрелә башлаячак.* Шәһри Чаллы

2) Сертификат алу процедурасы

**СЕРТИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Сертификация үткәрү

**СЕ́ССИЯ** *и. лат.* 1) Төрле вәкиллекле орган, оешма һ.б.ш.ларның эшчәнлеге өлкәсендә билгеле бер сроктан соң даими рәвештә яки зарури очракта уздырыла торган җыелыш. *Ягъни авыл советы сессиясендә каты тәнкыйть ителгән ферма мөдире Нургали --- тәнкыйть итүчеләргә күңеленнән рәхмәт укый башлый!..* Ә.Еники. *Күпләгән четерекле мәсьәләләрне күтәрде бу сессия утырышы*. Ә.Зарипов

2) Югары һәм махсус урта уку йортларында имтихан тапшыру чоры. *Институтта уку елларында күп тапкыр, сәгатьләр буе китап-дәфтәр битләренә чумып, сессия, зачётларга әзерләнгәннәре бар аларның бу яшь бакчада.* Г.Минский. *Бәйрәмнәр, институтта сессия тәмамланды, студентларның килер чагы җитте.* М.Маликова

**СЕСТРА** *и. рус* Урта медицина хезмәткәре; шәфкать туташы. *Санаторийга барып җиткәч тә, врачлар, сестралар кулыннан ычкыну белән үк, урамга чыктым.* Г.Әпсәләмов. *Вестибюльнең уң ягында, аралык артында, урындыгына чак сыеп, юп-юан сестра утыра.* А.Гыйләҗев

**СЕСТРАЛЫК** *и.* Сестра вазифалары һәм хезмәте. *[Фронтка җибәрегез, дип үтенүче кыз:] Мин сестралыкка укып чыктым, мин пулемёттан ата беләм, бөтенесен беләм!* Г.Бәширов

**СЕТ** *и. ингл. спорт* Теннис уенында бер партия

**СЕ́ТКА** *и. рус сөйл.* Азык-төлек һ.б.ш.лар салып йөртелә торган кечкенә ятьмә капчык рәвешендәге хуҗалык сумкасы. *Берәве ашыгып килеп керә – ходавәндә, сеткасы тулы тавык!* Р.Сәлим. *Рафаэль эшеннән төрле ризыклар төялгән зур сетка күтәреп кайтты.* Р.Мөхәммәдиев. *Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына, дигәндәй, шабашкадан баеп кайткан Торнаның кибеттән тулы сетка белән чыкканын күреп өлгердек.* Ф.Дәүләтбаев

**СЕ́ТТЕР** *и. ингл.* Озын йонлы, чыдам ау этләре токымы һәм шул токымга караган эт. *Күптәннән бу сеттерга кызыгып йөри иде инде ул.* Казан утлары

**СЁМГА** *и. бор. рус зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан Атлантик океанның төньяк бассейннарында күпләп очрый торган кыйммәтле промысел балыгы; сөмбаш. *Әйтик, тозланган сёмга балыгына һәм, гомумән, балык янына ак шәраб куела, ит белән киек янына – кызыл шәраб, ә кофе эчкәндә, ликёр белән коньяк муафикъ.* Р.Мирхәйдәров. *Сёмга (сөмбаш) балыгын кисәкләргә бүлеп, тоз һәм борыч сибеп, салкынча урынга куеп торабыз.* Сөембикә. *Шуны да белеп торыгыз: Норвегиядән китерелә торган сөмбаш (сёмга) сулыклардагы кечкенә генә ябык махсус корылмаларда үрчетелә.* Ватаным Татарстан

**СЁРФИНГ** *и. ингл.* 1) Махсус җиңел тактада бәрмә дулкыннар өстендә шуудан гыйбарәт спорт төре. *Зур адреналин бирә торган куркыныч спорт төрләре арасында сёрфинг – алтынчы урында.* Шәһри Казан. *Сёрфинг – бүген яшьләр арасында танылган экстремаль шөгыль.* Сөембикә

2) Дулкыннар өстеннән шуар өчен махсус такта. *Телисең икән – Милли парктагы храм диварларындагы майя иероглифларын карап йөр, телисең икән – комлыкта аркаңны кояшта кыздыр, телисең икән – сёрфинг белән дулкын өстендә тибрәл, телисең икән – акваланг киеп, су астында кораллар арасында йөзеп йөр.* Татарстан яшьләре

**СЁРФИНГЧЫ** *и.* Сёрфинг белән шөгыльләнүче спортчы

**СИ** *и. ит. махс.* 1) Музыкаль авазлар системасындагы соңгы, җиденче тон. *Музыкада да төп тавышлар җидәү: до, ре, ми, фа, соль, ля, си.* М.Мәһдиев

2) Музыка әлифбасындагы шушы тонны белдерә торган нота. *Консерватория тәмамлаган тенор тавышлы җырчылар өчен авыр булып саналган югары ля, си, хәтта до ноталарын аның җиңел алуы истә калган.* М.Макаров. *Хет берәрегез беләме икән сидан соң килгән нота ни булганын?* Ватаным Татарстан

**СИА́М ИГЕЗӘКЛӘРЕ** *и. күпл.* Бер күкәйдә яралып, эмбрион вакытында аерылып бетәргә өлгермәгән, кайбер әгъзалары уртак игезәкләр. *Явыз хатыннан аерылу ул – сиам игезәкләрен хирург пычагы белән кисүгә тиң, валлаһи газыйм!* Д.Гыйсметдин. *Тарихтан, әдәби әсәрләрдән үткән гасырларда туган сиам игезәкләрен, өч күзле, койрыклы кешеләрне беләбез.* Татарстан яшьләре

◊ **Сиам игезәкләредәй** *к.* **сиам игезәкләре кебек**. *Сиам игезәкләредәй бер-берсенә сыланган кешеләр тынгысызландылар: автобусның әле бер башында, әле икенче очында шырпыдай дөртләп ызгыш кабынды.* Ф.Җамалетдинова. **Сиам игезәкләре кебек** Берсеннән берсе аерылмый торган; бик якын. *Алар, сиам игезәкләре кебек, берберсе белән үзара тыгыз мөнәсәбәттә.* Х.Миңнегулов. *Икътисад белән сәясәт, сиам игезәкләре кебек, бер-берсенә береккән әйберләр.* Ватаным Татарстан

**СИБӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кат-кат сибү, тарату, чәчү (бөртекле яки вак нәрсәләр тур.). *Хәзер умач та уган юк инде юньләп. Онны шул көенә генә сибәлим ашка.* З.Зәйнуллин

2) Җиңелчә генә яву. *Сибәли дә юа яңгыр йөзен гөлнең.* Х.Туфан. *Җан көйдереп вак яңгыр сибәли.* А.Гыйләҗев. *Тик яңгыр һаман сибәли бит, каһәр.* Р.Зәйдулла

**Сибәләп алу** Аз гына сибәләү. *Кем әйтмешли, җырчылар да үз вакытында җырлап, яңгыр да үз вакытында сибәләп алды.* И.Шәрипова

**Сибәләп китү** Бераз сибәләп туктау. *Арыш арасында бертуктаусыз чикерткәләр сайрый, әллә нинди кошлар сайрый торган иде, үзенә бер тавыш чыгарып, әкрен генә, талгын гына башаклар чайкала, кояш кыздыра торган иде, кайчакларда яңгыры да сибәләп китәр иде.* Н.Фәттах. *Бөтен дөньяны томалап килгән яңгырның тиз генә сибәләп китмәсен белгән шикелле, күз яшьләремнең дә тиз генә кипмәсен мин чамалый идем.* М.Кәбиров

**Сибәләп тору** Күпмедер вакыт, бик озак, даими яки сөйләү моментында сибәләү. *Кич шактый салкын, һава болытлы, вак яңгыр сибәләп тора.* Ш.Камал. *Яңгыр һаман пычтыр-пычтыр сибәләп торды.* А.Гыйләҗев. *Бүген иртәдән үк яңгыр сибәләп тора менә.* Р.Зәйдулла

**Сибәли башлау** Сибәләргә тотыну. *Төштән соң, эш бетәргә бер-ике сәгать каларак, күк йөзен бөдрә болыт каплады, кыйгач бәреп, җылы яңгыр сибәли башлады.* С.Сабиров. --- *хәерчегә җил каршы, дигәндәй, җитмәсә, күңелләргә шом салып, ямьсез саргылт яңгыры сибәли башлый.* Т.Галиуллин

**Сибәли бирү** Һаман сибәләвен дәвам итү. *Урамда караңгы төшеп килә, тирә-як акрынлап билгесезлеккә күмелә, җитмәсә, яңгыры да туктамый, һаман сибәли бирә.* Л.Габдрахманова

**СИБЕЛМӘ** *с.* Таркау, таралып яки чәчелеп китә торган. *Н.М. Пржевальскийга һәм аның юлдашларына бик күп кыенлыкларны: биек тау сыртларын, чүлнең җансыз сибелмә комлыкларын, эсселекне һәм көчле салкыннарны... җиңеп узарга туры килә.* Материклар һәм океаннар географиясе

**СИБЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сибү** (*1–8 мәгъ.*). *Кырларга ашлама сибелә*

2) Тәртипсез таралып коелу, чәчелү. *Сибелә чәчәк, җилләр лә искәндә, Өзелә үзәк, исләремә төшкәндә.* Җыр. *Алмагач чәчәге сибелә, Җирләргә сибелә җилләрдә.* Х.Туфан. *Чәчәкләрнең җилдән сибелгәнен күргәнегез бармы?* Ә.Еники

3) Чыгып таралу, бөркелү (нур, ис һ.б.ш. тур.). *Керфекләре сирпелде, Йөзенә нур сибелде.* Х.Туфан. *Көнчыгыштан көлтә-көлтә алтын нурлар сибелә.* И.Салахов. *Тоныксу шәм яктысы диварларга сибелә...* Н.Гыйматдинова

4) Таралышу, төрле якка китү. *Кичке ярауда урамга чыгып сибелгән балаларның тавышлары ишетелә башлады.* А.Гыйләҗев. *Хафиз, әниләренең килгәнен күреп, үзе тиз генә кузлага күчте, малайлар чебешләр кеби читкә сибелделәр.* Г.Галиева

**Сибелә бару** Торган саен күбрәк сибелү

**Сибелә башлау** Сибелергә тотыну. *Пулемёттан чыккан пулялар читкә сибелә башлый.* З.Зәйнуллин. *Тукталышта трамвай көткән кешеләр, нигәдер ташкыннан өркегән җәнлекләр шикелле, тирә-якка сибелә башладылар ---.* Х.Ширмән

**Сибелә тору** Сибелүе дәвам итү. *Бармаклары кәгазь өстеннән шома гына шуган кебек, сүзләре дә залга тоткарлыксыз сибелә торды.* Ә.Баян

**Сибелеп бетү** Тәмам, барысы да сибелү. *Билгеле инде, фашист армиясе үзенең бөтен ут һәм тимер көче белән искәртмәстән бәреп кергәч, батальонның коралсыз солдатлары ихтыярсыз, сарык көтүедәй, тирә-якка сибелеп бетәләр.* Ә.Еники. *Коралдан түгел, аның усал йөзеннән, кан баскан күзләреннән куркып, тирә-якка сибелеп беттеләр.* Н.Фәттах

**Сибелеп китү** Кисәк сибелү. *Озак та үтмәс, сары газ лампалары сыман яп-якты каштан яфраклары бөтен җир өстенә сибелеп китәчәк.* Г.Рәхим. *Ялгыш сибелеп киткән сәйләннәрдәй, үләннәргә тамчы ятып көлә.* Л.Исхакова

**Сибелеп тору** Озак вакыт дәвамында, әледән-әле яки хәзер сибелү. *Бик матурсың, йөзләреңнән нур сибелеп тора.* Л.Шафикова

**Сибелеп яту** *сөйл.* Сибелгән хәлдә булу. *Бакый ага, үзенә багышланган тарихи миссияне тоеп, анда-монда сибелеп яткан ташларны җыйды да, билгеле бер тәртипкә китереп, милли сынлы сәнгатьнең гаҗәп диварын корды.* Р.Фәйзуллин. *Быел яңа келәт торгызырга уйлаган идем, әзер бүрәнәләрем капка төбендә сибелеп ята.* Н.Гыйматдинова

**СИБИЛЯНТ** *и. лат. лингв.* Тел алды фрикатив тартыгы (мәс., *с, з, ш, ж* авазлары)

**СИБҮ** *ф.* 1) Бөртекле яки вак кисәкле нәрсәләрне чәчеп тарату. *Сөннәт беткәч, бабай, хәл белер өчен, тагы әүвәлге йортка бара: «Менә тәти булган, углым», – дип, акырган балага тагы черегене сибеп, тагы чәй эчеп, тагы икмәк алып китә иде.* Г.Исхакый. *Юлда иртән тузан сибеп уйный углан.* Х.Туфан

2) Бөртекле тәмләткечләрне ашамлык өстенә бераз гына салу, аңа кушу. *Икмәгемә сибә алам ятлар тозын, Үз бәгъремне кәбаб итеп капсам гына.* Х.Туфан. *Каты пешкән икешәр йомыркага тоз сибеп, коймак белән ашадылар.* А.Тимергалин

3) Бөртекле яки вак кисәкле азыкны кош-кортка бирү, таратып салу. *Ул икенче чиләктәге бүрттерелгән борчакны учлап ала да сибә, учлап ала да сибә.* Г.Рәхим. *Хатыны абзарда тавыкларга җим сибә иде ахрысы, мине күрүгә, йөзен борды.* Р.Зәйдулла

4) Сыеклыкларны бөркү. *Яңгыр явып торганда, Иртән-иртүк торган да, Сулар сибә суганга, Сәбәп кирәк булганга.* Х.Туфан. *Хәзер аңа ниндидер бер җылы сүз әйтү янган йөрәккә бензин сибү кебек кенә булачак.* С.Поварисов

5) Нур, ис һ.б.ш.ларны тарату, чыгару, бөркү. *Яхшы ил син, Иран, мин беләм. Ал гөлләрең хуш ис сибеп утыра, Сөйләп миңа синең турында.* Х.Туфан. *Гел елмаеп кына, якты нурлар сибеп тора торган Нургалием үтә моңсу, сагышлы моңсу гына түгел, әллә ниндиди кайгы катнаш моң иде аңарда.* Г.Галиева

6) *сөйл.* Яву (яңгыр, кар тур.). *Бигрәк тә көзге яңгырларда, кыеклап сипкән яңгыр тәрәзәсез төньяк стенаны урын-турын чылатып куйган булса, йорт моңлы була.* М.Мәһдиев

7) *күч.* Чамасыз күп сарыф итү, күпләп өләшү-тарату. --- *хатыны янда чакта, акчаны уңга-сулга сибәргә яраткан Ренат, ялгыз йөргәндә, бер тиен өчен канга-кан килә иде.* А.Гыйләҗев. *Ә берәүләр акчаны казинода, уен автоматларында сибә.* З.Мәхмүди

8) *күч.* Берьюлы күп коралдан яки өзлексез рәвештә ату. *Пах! – Рамазан мылтыктан әле бер, әле икенче якка сипте.* Х.Ибраһим

9) *күч. сөйл.* Бик оста, җитез, матур итеп җырлау, бию, музыка уйнау һ.б.ш. *Кайбер шаянрак кызлар шыпырт кына җырны болай дип тә сибәләр.* М.Мәһдиев. *«Яратам» дигән сүзне борчак урынына сипте Алмабикә.* С.Поварисов

10) *күч. сөйл.* Оялмыйча, тартынмыйча сөйләү; уйламыйчарак артык күп сөйләү; ялганлау. *Тыштан ялтырап исәнләшә, аны өнәгән, хуп күргән сүзләр сибә, әмма артта бөтенләй башка төрле иде.* Х.Камалов. *Ә мин, дорфа кызыкай, уйлап та тормастан, аңа юләр сүзләремне сиптем.* Л.Хөсәенова

**Сибә бару** Бер-бер артлы өзлекле рәвештә сибү. *Юлда кыйммәтле ташларны сибә бара, кызлар шуны җыеп калалар.* Әкият. *Утыртылган берсенә, шиңмәсен өчен, су сибә бардылар.* А.Алиш

**Сибә башлау** Сибәргә тотыну. *[Дошман] кинәт пулемёттан сибә башлый.* И.Гази. *– Абзар янында гына ут яккансыз, пожар чыгарасыз бит, малай актыклары! – дип сөйләнә-сөйләнә, учагыбызга туфрак сибә башлады.* Р.Гариф

**Сибә бирү** Бернигә дә карамый сибүен дәвам итү. *– Акча түләп ялла-ганмыни, түшен киереп баскан да Бикташтан бакчаларына безнең мичкәдән шабыр-шобыр су сиптертә! – Соң үзе риза икән, сибә бирсен!* М.Маликова

**Сибә тору** Һаман сибүен дәвам итү. *Шулай да «хәзерге яшьләр бозык» дигәнрәк сүзләрне тагын бик озак һәм пычрак су сымак туктаусыз сибә тордылар.* Ә.Баян

**Сибеп бетерү** Беткәнче сибү; бик күп сибү. *Өч чиләк бензинның тамчысын да калдырмыйча, елый-елый сибеп бетергәч, кочак-кочак күтәреп, өйнең дүрт ягына да салам ташыды.* Н.Гыйматдинова

**Сибеп җибәрү** Кинәт сибү. *Әмма ул [Зөфәр] дәшмәде, савыттан чеметеп кенә тоз алып, шулпасына сибеп җибәрде.* А.Гыйләҗев. --- *саранлансам, юлым уңмас дип, чирәмгә куш учы белән кызыл билле прәннек сибеп җибәрде [Габбас мулла].* Г.Ахунов

**Сибеп кую** Алдан сибү; бер мәртәбә сибү; тиз генә сибү. *Мирсәетне булдереп, шунда берәве ярага тоз сибеп куймасынмы.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул Сәмәрия ихатасына тоз сибеп куйганнар микән – бөтенесе дә шунда җыелыша.* Р.Камал

**Сибеп ташлау** Тиз арада яки кинәттән сибү. *Нурия, батырлыгын җыеп, бер әйтүдә, пулемёттан сиптергән төсле, сүзен сибеп ташлады.* Г.Ахунов

**Сибеп тору** Даими рәвештә, озак кына яки сөйләү моментында сибү. *Кысык Минҗан дөрләп янган утка керосин сибеп тора.* Г.Ахунов. *Ак күлмәк, чәчкәле галстук аның йөзенә матурлык нуры сибеп тора кебек.* С.Поварисов

**СИГ** *и. норв. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан көмеш гәүдәле, сырты, йөзгечләре карарак төстәге балык; алабалык

**СИГА́РА** *и. исп.* Таякчык формасында тыгызлап төрелгән тәмәке яфрагы. *Насретдин абзый өметле генә кызган һәм авызына безнең авылда моңарчы күренмәгән юан сигара капкан иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул сигарасын, сүндереп тә тормыйча, идәнгә атып бәрде.* А.Тимергалин

**СИГА́РАЧЫ** *и.* 1) Сигара эшләүче, яки эшләп чыгаручы, яисә шуның белән кәсеп-сәүдә итүче

2) Сигара тартучы

**СИГАРЕТ** *и. исп.* Юка кәгазьгә төреп эшләнгән мөштексез папирос. *Шофёр егет, колак артына кыстырган сигаретын купшы гына кабызып: – Кая, кая? Кайсы авылга кайтасыз? – дип кабатлап сорады.* А.Гыйләҗев. *Стен сигаретын таптап сүндерде дә, җиргә куйган портфелен алып, станциянең үзәк бинасына таба атлады.* А.Тимергалин

**СИГАРЕТЛЫ** *с.* 1) Эчендә сигареты булган, бушамаган (кап һ.б.ш. тур.)

2) Үзе белән сигареты булган яисә авызына сигарет капкан (кеше тур.)

**СИГАРЕТЛЫК** *с.* Сигарет алырга дигән яки шуңа җитәрлек (акча тур.). *– Яхшы сигаретлык акчаң юкмы әллә? – дип гаҗәпләнде майор.* Ф.Бәллүр

**СИГӘК** *с.* 1) Боелыгын тота алмаган яки йоклаганда астына сия торган. *Ә кендек кыска яки озын киселсә, бала сигәк була, дигән ышану бармы?*

Фольклор практикасы. *Кайсы дебил, сигәк, юләр – андыйларны эшкә алырга да теләмиләр, «кәҗә билеты»н карагач.* Безнең гәҗит

2) *сөйл.* Хурлап, ачуланып, тиргәп әйтелә торган сүз. *Икенче көнне Шәмсия, сөенечен уртаклашырга теләп, үзалдына сөйләнә: --- Казаннан зимлямир килеп, бакчаларымны үлчәп китте, Сигәк Хәсәнне Себергә кудырып, бәрәңге җирләрен миңа бирдерәм, диде ---.* К.Кәримов. *Шул сигәк марҗаңны һаман да оныта алмадың инде!* Ватаным Татарстан

**СИГӘКЛӘНҮ** *ф. к.* **сигәкләү** (*1 мәгъ.*)

**СИГӘКЛӘ́Ү** *ф. гади с.* 1) Боелыгын тота алмау (авыру тур.)

2) *күч.* Ялагайлану, әләкләү, тиешсезгә зарланып елау һ.б.ш. гадәтләре булу. *Сигәкләп йөрүче куштан*

**СИГЕЗ** *сан* 1) Җидедән соң килеп, 8 санын, микъдарын һәм цифрын белдерә. *Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра.* Мәкаль. *Сигез каралтыдан берьюлыургылып чыккан аклы-каралы төтен бер-берсе белән янәшә диярлек утырган тирә-як авыллардан да үзенә кешеләр чакырырга тотынды.* А.Гыйләҗев

2) Сигез яшь. *Менә ул, нибары сигезе тулып, тугызга чыгып килгән Канәгать Сибгатуллин абзагыз, берүзе дип әйтерлек, уналты сутый бакчаны күмдереп чыкты.* А.Хәлим

3) **сигезе**. Сигезенче число; календарь аеның сигезенче көне. *Бишесе, алтысы, җидесе, сигезе ял иде.* М.Мәһдиев. *Мәҗлес майның сигезенә туры килде.* Ватаным Татарстан

◊ **Сигез көтә тугыз кат** Бик еш (кабатлану, булып тору тур.)

**СИГЕЗАЯК** *и. зоол.* Башаяклы моллюскларның бер төре булган көчле зур сигез капшавычлы ерткыч диңгез хайваны; спрут. *Диңгез төбендә шар күзле, юан, салмак-ваемсыз балыклар, кыслалар, краблар, йолдызлар, еланбалык, сигезаяк һәм меңләгән кабырчыклар, әкәм-төкәмнәр яши.* Р.Батулла. *Кинәт куркыныч туганда, сигезаяк, кальмар яки каракатица бездән чыккан сыекчаны, кара яки көрән болыт рәвешендә, бүрәнкә аша тышка бөрки һәм үзенә ташланган дошманыннан кача.* Биология

**СИГЕЗӘР** *сан* Сигез-сигез итеп бүленүне, һәрберсенә сигезәр тиюне белдергән бүлү саны. *– Гариф исемле егет – менә шушы егет инде ул! Сигезәр потлы капчыкларны уйнатып ала торган егет, – диде [Хөснеттин].* Ш.Камал. *Шул йола искә төшкәч, мин дә балконда бөкрәеп әйбер ала яздым, тик аяк астымда сигезәр килолы гантельләр генә иде.* М.Мәһдиев

**СИГЕЗӘРЛӘП** *рәв.* 1) Сигезәр-сигезәр итеп; сигезәргә бүлеп. *Тәрбияче балаларны сигезәрләп бастырды да яңа уенның кагыйдәләре белән таныштырды.* Ялкын

2) Сигезәр-сигезәр булып тезелү, урнашу, бүленү һ.б.ш. турында. *Сафка сигезәрләп баскан солдатларга карап, үзенең яшь чакларын искә төшерде Гали.* Сөембикә

**СИГЕЗӘ́Ү** *сан* **1.** Барысы, барлыгы сигез булуны белдергән җыю саны. *Назыймнарның үз алмагачлары да бар, сигезәү хәтта.* М.Хуҗин. *Рустик баскан урынында кыбырсына башлады, чөнки кәгазьләр – тугыз, ә кызлар сигезәү генә.* Х.Ширмән

**2.** *рәв. мәгъ.* Сигез зат бергәләп, сигезе берьюлы. *Бер палатада сигезәү яттык бит без ул вакытта.* И.Нуруллин. *Ике кешелек кенә чанага алтау да, сигезәү дә менеп төялгәннәр.* А.Хәсәнов

**СИГЕЗЕНЧЕ** *сан* **1.** Бер-бер артлы санаганда, урыны җиде белән тугыз арасында булуны белдергән тәртип саны. *Барыс елының сигезенче ае, икенче көне иде.* Н.Фәттах. *Ә мин менә инде сигезенче тәүлек тынчу карцерда җәфаланам.* И.Салахов

**2.** *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса шуңа туры килгән үлчәмен, номерын яисә кемнең дә булса мәктәптә укыган сыйныфын белдерә. *12 нче мәктәпкә килеп төпләнгәч, сигезенчеләр дә, Мишәр Кәбәй дип, аның күзен дә ачтырмыйлар, шундыйрак бер кәмит күрсәтергә ниятлиләр.* К.Миңлебаев. *Мәктәптә исә гаҗәеп тынлык: сигезенчеләр белән унынчыларның чыгарылыш имтиханнары.* Г.Якупова

**СИГЕЗЛӘП** *сан* **1.** Якынча сигез булуны белдергән чама саны. *Әлегә аяз торган көннәрнең кадерен белеп, берьюлы сигезләп комбайн уракка төшкән.* А.Хәсәнов. *Бүгенге көндә аның төрледән-төрле сигезләп гармуны бар.* Т.Нәҗмиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сигез зат бергәләп, сигезе берьюлы. *Сигезләп янгынчы мин төшәсе урынга таба җәймә тотып йөгерә...* Р.Батулла

2) Сигез итеп, сигездән. *Сигезләп ишкән чыбыркы*

**СИГЕЗЛЕ** *с.* **1**. 1) 8 санын белдерә торган. *Анда чәчәкләр арасыннан шат елмаешып торучы хатын-кыз рәсемнәре һәм буйдан-буйга сузылган сигезле саны бар иде.* Л.Хәмидуллин

2) Шул үлчәмдәге зурлыкны белдерә торган. *Бүгенге яшь укучы (әгәр ул минем бу әсәремне укыса) өчен аңлатып үтим: чалгылар авыл халкында шулай йөртелә – алтылы, җиделе, сигезле. Ягъни алтмыш, җитмеш, сиксән сантиметрлы.* М.Мәһдиев. *Иң беренче булып сигезле чалгысы белән Хуҗа абый кереп китә, аннан Миңнулла, Гыйниятулла, Хөсәен абыйлар – барлыгы егерме дүрт кеше.* Р.Газиз

**2.** *и. мәгъ.* 1) 8 цифры. *Сигезлене матур итеп яза белмәү. Гарәп һәм рим цифрлары системаларында сигезленең төрлечә күрсәтелүе*

2) Уен карталарында сигезенче номер белән билгеләнә торган карта. *Борчылма [тугызлы], үкчәң белән сигезлене рәхәтләнеп изә аласың – күрәсеңме, син дә властьта, җанашым!* А.Әхмәтгалиева

**СИГЕЗЛЕК** *и.* Сигез күзле уен картасы. *Буби сигезлеге. Уен сигезлеге*

**СИГЕ́ЗЬЕЛЛЫК** *с.* **1.** 1) Тулы булмаган гомуми урта белем бирә торган (мәктәп тур.). *Ә менә нигә: колхозның балалар бакчасы юк, безнең балалар үстерәсебез килә. Аннары: колхоз үзәгендә сигезьеллык мәктәп.* М.Мәһдиев. *Үзебезнең авылда – башлангыч, күрше Шәңгәлчедә – сигезьеллык, Түбән Камада урта мәктәп тәмамлаганнан соң, мин башта – Казанга, аннары Мәскәүгә укырга китеп бардым.* Р.Вәлиев

2) Сигез елга планлаштырылган, билгеләнгән, исәпләнгән (план, бурыч һ.б.). *Үткән сигезьеллык зур уңышлар, нәтиҗәләр белән тарихка кереп калды.* Ватаным Татарстан

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сигез елдан торган чор, вакыт аралыгы

2) Сигез еллык мәктәп. *Рәмзи – сигезьеллыкны мактау кәгазе алып тәмамлаган малай.* Г.Бәширов

**СИГНАЛ** *и. лат.* 1) Төрлечә хәбәр тапшыру-белдерү өчен кулланыла торган шартлы элемтә чарасы. *Яктылык сигналы. Механик сигнал. Автомобильнең сигнал уты*

2) Шул чарадан файдаланып бирелә торган шартлы хәбәр, шартлы команда. *Галимҗан ага Нигъмәти карандаш төпчеген ыштан бөрмәсенә яшерергә өлгермәде, күрше дивардан чакыру сигналы чирттеләр.* И.Салахов. *Кабинадан башын сузган шофёр озын итеп сигнал бирде.* Л.Шафикова

3) Гомумән, берәр төрле хәбәр, боерык, чакыру. *Әгәр кинәт сигнал була калса, Без һәммәбез торып китәрбез.* Х.Туфан

4) *махс.* Берәр нәрсәнең булуынъяшәвен, хәрәкәтен белдергән-күрсәткән билге; аның организмга яки аппаратка тәэсир итү чагылышы. *Шулай да миенең кайсыдыр почмагында исән калган күзәнәк исәнләшергә кирәген искә төшереп сигнал биреп тора.* Р.Зәйдулла

5) Берәр житешсезлек турындагы кисәтүле хәбәр. *Якуп, сезнең эшегездә нинди дер чатаклыклар бар икән бит. Шул турыда сигналлар да бар.* Р.Ишморат

**СИГНАЛИЗА́ТОР** *и. рус* Сигнал бирү җайланмасы-аппараты; шуның сигнал тапшыра торган өлеше. *Ул арада дистанция щитында, кызыл утын уйнатып, сигнализатор гүелдәргә тотынды.* Ч.Айтматов. *Мичтә сигнализатор тора.* Татарстан яшьләре

**СИГНАЛИЗА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Сигнал (*1 мәгъ.*) тапшыру хезмәте, сигнал ярдәмендә хәбәр бирү эше. *Ә мин, сигнализация тавышлары яңгыраган саен, сикереп торам да балконга йөгерәм.* Д.Гыйсметдин. – *Тә-әк, – диде Нургали, машинага карап, – беренче эш итеп сигнализация проводын өзәргә кирәк.* Г.Галиев

2) Сигналлар (*1 мәгъ.*) системасы. *Диңгез сигнализациясен өйрәнү*

3) Сигнал җайланмалары-аппаратлары системасы. *Тимер ишек тә куелмаган, сигнализация дә юк.* М.Кәбиров. *Каравылчы штатын кыскарттылар, барлык кибетләр төнгелеккә күзәтчесез калды. Сигнализация көйләү хәстәрен күрмиләр.* Ә.Моталлапов

**СИГНАЛЧЫ** *и.* Сигнал (*1 мәгъ.*) бирүче. *Берничә секунд та үтмәде, сигналчы, коты очып, ике кулын үзара кисештерә-кисештерә туктатырга кушты.* Н.Хәсәнов. *Сигналчы һәм телеграфист-элемтәче буларак, Ленинград, Кронштадт, Таллин, Сталинград тирәләрен дә урый ул.* Т.Нәҗмиев

**СИДЕК** *и. физиол.* Кеше һәм хайваннар организмыннан бөер аша бүленеп чыга торган сыекча; бәвел. *Ай буена хәмер, тәмәке, сидек, косык һәм башка яман исләргә күмелеп яшәгән бүлмә тиз генә адәм рәтенә керергә ашыкмый иде.* М.Кәбиров. *Таш-бетон панельләрдән җыеп салынган терлек абзарының волейбол мәйданы чаклы ишекләрен ачып керүгә, төче силос, әче сидек исе белән туенган җылымса һава борынга бәрелде.* А.Вергазов

**СИЗГЕР** *с.* 1) Сизү тойгылары һәм хисе үткен, яхшы булган; тиз сизүчән. – *Әйдә, алай булгач.* – *Сизгер күңелле кыз Ирекнең кыенсынганын тойды.* Р.Хәбибуллина. *Бу яктан язучылар – иң сизгер, иң нечкә тоемлы халык.* Р.Низамиев. *Гафур йокыга сизгер иде, тиз уянды.* Н.Гыйматдинова

2) Уяу. *Кырыс тормыш сизгер булырга өйрәткән: без шып итеп туктап калдык.* Ә.Салах. *Гариф Ахунов тел бизәкләренә ифрат сизгер шәхес иде.* Т.Галиуллин

3) Нечкә күңелле, хискә бирелүчән, хисләрне аңлаучан. *Шуның өстенә хатын-кызның үтә сизгер йөрәге күп нәрсәне ялгышмый тоя бит.* Г.Әпсәләмов. *Ул иң элек әдәбият алдында тормыш үзе куйган мөһим бурычларны үз вакытында тотып ала торган сизгер күңелле язучы буларак танылды.* Р.Зарипова

**СИЗГЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Сизгергә әйләнү, сизгер булып китү. *Дәрт-дәрманы артып кына калмыйча, хисләренә кадәр сизгерләнә, нечкәрә аның.* М.Хәсәнов. *Чөнки ул чакта аның зиһене кылны кырыкка ярырлык булып сизгерләнә, хисләре нечкәрә, дәрт-дәрманы ургылып чыга.* Ф.Садриев

2) Сизгерлек күрсәтү. *Куркыныч килер алдыннан, тойгылар шулай сизгерләнә.* М.Юныс

**Сизгерләнә бару** Торган саен ныграк сизгерләнү. *Үзем дә су төменә сизгерләнә барам.* Ш.Маннапов

**Сизгерләнә төшү** Тагын да сизгерләнү. *Олыгайган саен, тагын да сизгерләнә төштем бугай мин.* Г.Ахунов

**Сизгерләнеп бетү** Тәмам сизгерләнү. *Ауга йөри-йөри, этем тәмам сизгерләнеп бетте.* Ватаным Татарстан

**Сизгерләнеп китү** Соңгы вакытта сизгерләнү. *Хәзер җыр тыңлаганда да, шигырь укыганда да, аның күңеле кузгалып, зиһене сизгерләнеп китә.* М.Маликова

**СИЗГЕРЛЕК** *и.* Сизгер булу сыйфаты. *Күрше кадерен, туганлык хисләрен, ризык кадерен аеруча сизгерлек белән тоялар алар.* Ә.Салах. *Ни өчен эштә политик сизгерлек җитешми?* Х.Камалов

**СИЗДЕ́РМӘСТӘН** *рәв.* 1) Сиздермичә, белдермичә, әйтмичә; качып, яшереп. *Ул сиздермәстән һөҗүм итмәсен өчен, лагерьны арбалар, казыктан, чыбыктан үрелгән читәннәр белән уратып алалар.* З.Мурсиев. *Сиздермәстән барып керергә тиеш идек.* М.Яһудин

2) Сизелмичә (вакыт, гомер узу һ.б. тур.). *Яшь вакыт – чәчәк вакыт: сиздермәстән әнә шулай узар да китәр.* Г. Бәширов

**СИЗДЕ́РМИЧӘ** *рәв. к.* **сиздермәстән** (*1 мәгъ.*). *Билгеле, мин бу сүзләргә читтәнрәк, сиздермичәрәк колак салып утырам.* Ә.Хәсәнов. *Сиздермичә генә көндәлегеннән укыдым.* К.Кәримов

**СИЗДЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* 1) Сизәргә (*2, 4 мәгъ.*), белергә мөмкинлек бирү. *Күрешкәндә, салкынлыгын сиздерү өчен ахры, бармак очларын гына сузган Сәгыйдә дә кинәт ачылып китте.* Г.Галиева. *Кешедән калышу, эшеңнең*

*рәте-чираты булмавын сиздерү – бик зур оят.* З.Мурсиев

2) Нииндидер күренмәгән сыйфатларны, билгеләрне белдерү, күрсәтү, ачу. *Көннәр үткән саен, авырту үзен ныграк сиздерә кебек.* Ф.Яруллин. *Карбураннары, салкын көннәре белән кыш үзенең китәсе килмәвен сиздерә иде безгә.* Сөембикә

3) Теләк, ният, уй һ.б.ш.ларны читләтеп кенә аңлату, өлешчә генә белдерү. *Гаяз, җавап көткәнен сиздереп, бераз тукталып торды.* М.Әмир. *Ә кияү дигәне Мәһирәсенә күз ташлап, сүзнең никах турында икәнен сиздерү өчен: «Сөенечләр уртак булсын», – дип елмайды.* Г.Галиева

**Сиздерә бару** Торган саен ныграк сиздерү. *– Ашыкма син, хисләреңне әкренләп сиздерә бар, – дияр иде әбием.* Г.Галиева

**Сиздерә башлау** Сиздерүгә табан үзгәрү. *Көн үткән саен, ялгызлык үзен ныграк сиздерә башлады.* Ә.Еники. *Кайда ялган бар, анда намус төшенчәсе, намус тойгысы үзен югалта яисә барлыгын бөтен көченә сиздерә башлый.* Ф.Яхин

**Сиздерә килү** Күптәннән бирле сиздерү. *Вакытында Деникинга каршы сугышкан гаскәрләрдә шәфкать туташы булып йөргән бу кыз композитор егеткә булган хисләрен яшертен генә сиздерә килде бугай.* Р.Низамиев. *Үземнең моңа каршы булуымны мин ел дәвамында сиздерә килдем.* Заман сулышы

**Сиздерә тору** Вакыт-вакыт сиздерү. *Староста моны кичермәде. Әледән-әле дошманлыгын сиздерә торды.* Т.Нәбиуллин

**Сиздерә төшү** Тагын да ныграк сиздерү; бераз гына сиздерү. *Торган саен ялгызлык үзен сиздерә төшә икән шул.* И.Нуруллин

**Сиздереп кую** Аз гына, бер тапкыр сиздерү. *Ул арада, зәһәр үкереп, теге җан иясе үзенең барлыгын сиздереп тә куйды.* Г.Гыйльманов

**Сиздереп тору** Һәрдаим сиздерү; әледән-әле сиздерү; хәзер, сөйләү моментында сиздерү. *Алар аның ак һәм чиста, холкының тигезлеген, сабырлыкта камиллеген сиздереп торган кал-ку бит очыннан йөгереп төшәргә тиеш иделәр, әмма озын кара керфекләренә эленеп калудан уза алмадылар.* Ф.Яхин. *Маңгаеннан чыккан бөрчек-бөрчек тир тамчылары, үзеннән аңкып торган аракы исе Саматның эчке халәтен әллә каян сиздереп тора.* Ватаным Татарстан

**СИЗЕЛЕРЛЕК** *с.* **1.** Сизәрлек; шактый; игътибарны җәлеп итәрлек. *Ул сизелерлек сәрхуш бугай, безнең баркастан сузылган чалканы тумбага элгәндә, нәрсәгәдер абынып, чүт егылмады.* С.Сабиров. *Бу уйнап кына башланган хәрби сәфәрнең Урда өчен сизелерлек югалту белән тәмамлануында Мамайның бер катнашы да юк иде.* М.Әмирханов

**2.** *рәв. мәгъ.* Күзгә күренеп, шактый, аермасы күренерлек дәрәҗәдә. *Малай кинәт кенә үскән кебек булып, терелләнгән, сизелерлек әйбәтләнгән.* Х.Камалов. *Кысан машинада оеган идеме, уң аягына сизелерлек аксап бераз йөренде дә күн чабатасын салмый гына брезент читенә кырын ятты.* К.Кәримов

**СИЗЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сизү**

2) Тою органнары аша тышкы тәэсир кабул ителү. *Ачык тәрәзәдән җылы җил бәрелгәне сизелә.* И.Хуҗин

3) Төрле тышкы билгеләрдән беленү, күренү, аңлашылу. *Аның тавышында җиңелчә генә калтырау һәм ясалма зарлану сизелә иде.* Ф.Әмирхан. *Кардиналлар арасында курку да, ризасызлык та сизелә.* Р.Батулла

4) Беленү, ачылу, фаш булу (сер, хәйлә һ.б.ш. тур.). *Кайда соң бу Зөләйха ханым, күренми, сизелгәнче тизрәк сызасы иде бит.* М.Фәйзи. *Либреттоны тыңлаган вакытта, берничә җитди кимчелегә сизелде.* М.Җәлил

**Сизелә бару** Торган саен ныграк сизелү. *Гомер узган саен, Тукайның кыйммәте ныграк сизелә бара, ул безгә ел саен якыная, халыкның аңа мәхәббәте көчәя бара.* Г.Бәширов. *Шул ук вакытта аларда рус теленең татар теленә тәэсире сизелә бара.* Р.Йосыпов

**Сизелә башлау** Сизелергә тотыну. *Фәгыйлә апа җырларга тотынгач, шундук дәртле бер җанлану сизелә башлады.* Н.Фәттах. *Болай да чырае чытыла башлаган судьяның шул ук чыраенда җирәнү галәмәте сизелә башлаган иде.* Ф.Баттал

**Сизелә килү** Күптәннән бирле, электән үк сизелү. *Егетләрнең кыңгыр эшләре соңгы елларда сизелә килде, тик беркем дә каршы төшә алмады.* Г.Ибраһимов

**Сизелә тору** Әледән-әле сизелү

**Сизелә төшү** Тагын да ныграк сизелү. *Булганны яшереп булмый ул: кызының көмәнле булуы тагын да сизелә төште.* Сөембикә

**Сизелеп кую** Аз гына сизелү. *Больница янында гел басынкыланып калган иде, ә хәзер аның тавышында чаялык сизелеп куйды.* Р.Вәлиев. *Ләкин шул сүзләр арасына урыс та, татар да аңламый торган сүзләрнең дә килеп кысылганлыгы сизелеп куя.* Ф.Баттал

**Сизелеп тору** Һәрдаим сизелү; озак вакыт дәвамында сизелү. *Иҗадилык аның һәр эш-гамәлендә, һәр шигъри юлында сизелеп тора.* Х.Миңнегулов. *Гаиләнең ипи-сөткә тилмереп яшәмәве әллә каян сизелеп тора.* М.Афзалова

**СИЗЕМ** *и.* 1) Сизү органнары белән тою күренеше. *Утар дөньясын бары тик тоем, сизем аша гына аңлап-аңлатып буладыр.* Г.Гыйльманов

2) Интуиция. *Һәрбер һөнәр ул тирән булырга тиеш, тирән белем һәм дәрәҗәле сизем кирәк.* Р.Вәлиев

**СИЗЕМЛӘ́Ү** *ф.* Якынча сизү, чамалау; сизә-сизенә башлау. *Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләпсәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр – мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар.* А.Гыйләҗев. *Әнисе кызының йөзенә, күзләренә, тал чыбыгыдай сыгылмалы гәүдәсенә бәреп чыккан афәтне сиземли, сөйләргә мәҗбүр итә.* Т.Галиуллин

**Сиземләп алу** Бик тиз сиземләү. *Шулай да гомеремдә беренче тапкыр кеше дигән җан иясенең искиткеч нәзберек, искиткеч катлаулы, аңлашылмас рәвештә аяу җанлы икәнен сиземләп алдым.* В.Юныс. *Чикерткәләр корбанын (яки ризыгын) озын мыек очы белән сиземләп ала һәм эләктерә, ә саранчага зур һәм яхшы күрә торган күзләре ярдәм итә.* Безнең гәҗит

**Сиземләп калу** Сиземләргә өлгерү

**Сиземләп тору** Һәрдаим сиземләү. *Заманының бөтен әзәрлекләү механизмын үзендә тоемлап-сиземләп торган әдипнең башына тай типмәгән ләбаса!* Р.Әмирхан. *Моның мәгънәсе бик тирән дип аңладым: дәрәҗәле командирлар Казан вакыты белән Мәскәү вакытының бердәм агышын, тынычлык кыйммәтен, утлы корал белән шаярырга ярамаганлыгын һәрвакыт тоеп-сиземләп торсыннар!* Татарстан яшьләре

**Сиземли башлау** Сиземләү, тою, аңлау барлыкка килү. *Бер сәгать уздымы, бер гасырмы – берзаман хатын нәрсәдер тоя, нәрсәдер сиземли башлады.* М.Яһудин. *Әлеге үзгәрешләрнең үз файдама булачагын сиземли башладым бит, егетләр.* Ватаным Татарстан

**Сиземли төшү** Тагын да ныграк сиземләү; бераз сиземләү

**СИЗЕМЛЕ** *с.* 1) Яхшы тоючан һәм сизүчән; сизгер. *Кечкенә башлы редакторның күзләре дә чепи иде. Әмма елгырлар. Сиземлеләр.* Ф.Яхин. *Бездә кызлар сиземле.* Д.Салихов

2) Үтә сизгер һәм төгәл (аппаратлар тур.). *Аеруча сиземле сейсмик аппаратлар*

**СИЗЕМЛЕЛЕК** *и.* 1) Сиземле булу үзлеге. *Зәйнәп ханым кара бөдрә чәчле, кыйгач кашлы, шәфкатьлелек нурлары сибелеп торган зур коңгырт күзле, зифа буйлы ханымга соклана һәм, җырчы нинди генә әсәр башкармасын, нечкә музыкаль сиземлелек белән, Шәфыйка ханымга гына хас нәфислек, мөлаемлык белән башкаруын ассызыклый.* Ф.Арслан

2) Сизгерлек дәрәҗәсе. *Аппаратның сиземлелеге*

**СИЗЕМЧӘН** *с. сир.* Тою үзлеге көчле булган, сизгер. *Әти безнең бик сиземчән, һава торышы үзгәрәсен алдан белеп тора.* Казан утлары

**СИЗЕНҮ** *ф. кайт. юн.* 1) Ният, сер һ.б.ш.ны беркадәр белеп, аңлап алу; чамалау; өлешчә сизеп тору. *Ни уйлаганнарын сизенәм. Кызыксыналар, шикләнәләр.* Ә.Хәсәнов. *Халык күзенә чалынмаска тырышалар, шулай да күпләр хикмәтнең асылын сизенә.* Ә.Моталлапов. *Безнең кай тирәдә югалганны сизенә ул.* К.Кәримов

2) Абайлап алу. *Ул үзенең төзәтеп булмастай зур ялгыш эшләвен сизенеп, каушап китте.* Г. Бәширов

**Сизенә бару** Тагын да ныграк сизенү. *Көн үткән саен күбрәк сизенә бардым, сизенгән саен нәфрәтем артты.* И.Гази

**Сизенә башлау** Чамалау, беркадәр сизенү. *Шуннан соң дию пәрие сизенә башлый.* Әкият. *Берсе икенчесенең сүзләрен кабатлауларыннан алар сөйләшер темалары беткәнлеген сизенә башладылар.* Ф.Яхин

**Сизенә килү** Электән үк, күптәннән сизенү. *Сизенә килде Нияз, тик берни эшли алмады.* Кызыл таң

**Сизенә төшү** Бераз сизенү; күбрәк сизенү. *Теге тыныч кына, инде нидер сизенә төшеп, ихтимал, хатынының тавышын искәрептер, бераз дулкынланып җавап бирә икән.* Г.Бәширов. *Хәзер мин тагын да сизенә төштем, хәйләңне аңладым.* Казан утлары

**Сизенеп алу** Тиз арада сизенү. *Фатыйманың бу яшерен эшен әбисе белән бабасы сизенеп ала, «тыятырга» җибәрмиләр.* Р.Батулла. *Алар эшче яшьләрнең тулай торагына урнашып яши башлаган көннәрендә үк, минут эчендә сизенеп алып, бүлмәдәш кызларына дус егетләре кунакка килде.* Ф.Яхин

**Сизенеп тору** Һәрвакыт, гел сизенү; хәзер, сөйләү моментында сизенү. *Бераздан Муса хәтта аякларына махсус киез аслы туфли кигән надзирательләрнең, мәче сыман йомшак кына басып, ишек турыннан үтеп йөргәннәренә кадәр сизенеп тора башлый.* Р.Мостафин. *Кара, эте ничек сизенеп тора барысын да!* Ф.Яхин

**СИ́ЗМӘСТӘН** *рәв.* Үзең абайламаган, сизмәгән хәлдә; кинәт, көтмәгәндә, уйламаганда. *Үзе дә сизмәстән, кусәген күкрәгенә кысып, Хәлим дә алгарак омтылды.* Г.Ибраһимов. *– Карарбыз әле кем кемне икәнен, – дип мыгырдадым мин, үзем дә сизмәстән.* З.Мәхмүди

**СИЗРӘ́Ү** *ф.* Кыршылып-юкарып, сирәкләнеп, туза төшү (тукыма һ.б.ш. тур.). *Бердәнбер күлмәге дә юа-юа сизрәгән иде.* И.Нуруллин. *--- хәер, ремонт та әллә нәрсә кирәкми, чөнки Мөхәммәтхан шулкадәр пөхтә егет иде ки, аның чалбарының бер тез башы сизрәгәндә, икенчесе дә сизри һәм, ялга кайткач, әнисе аңа нәкъ бер зурлыкта, бер төстә ямаулар салып җибәрә иде, әйтерсең ул ямаулар фасон өчен.* М.Мәһдиев

**Сизрәп бетү** Тәмам сизрәү. *Кайсы авылга барганын белә күпертмән корсак, безнең татар-керәшен балалары икәнне дә күреп тора: керәшен малайларында балагы тездән генә зәңгәр киндер ыштан, төймәсез изүле юып сизрәп беткән киндер күлмәк...* Шәһри Казан

**Сизрәп калу** Сизрәгән хәлгә килү. *Аның башында уңып, ямьшәеп беткән кубанка, өстендә сизрәп калган шинель иде.* Ш.Маннур

**Сизрәп чыгу** Бөтенләй сизрәү

**Сизри төшү** Тагын да ныграк сизрәү; бераз сизрәү. *Минем матбагамда басыла торган газета, журналлар белән китаплар гына түгел, афишалар белән гади листовкалар да шундый кәгазьдә басылсыннар: бер кырыйларыннан тотып торган чагында, алар калай такта шикелле ялтырап, катып торсыннар, бөгелмәсеннәр, сынмасын, сәлперәп-сизрәп төшмәсеннәр, ди торган иде.* Гасырлар авазы

**СИЗҮ** *ф.* 1) Тою органнары ярдәмендә тышкы тәэсирне кабул итү. *Исне бик әйбәт сизә инде ул, беләсең бит.* И.Гази. *Шашлык исен башкалар да сизде.* З.Мәхмүди

2) Хис итү, күңел белән тою. *Без дусларың янында бит, үзеңне ялгыз итеп сизмә әле бер дә.* Г.Ахунов. *Иреннән калгач, керфеге кипмәде Зөләйханың, әтисен үтереп, барлык мөлкәтләрен талап алганнары күз алдыннан китмәде, шуңа күрә үзен дә гаепле итеп сизде.* М.Кәбиров

3) Хайваннарда: тою органнары ярдәмендә, гадәттә истән белү, табу. *Җавапны теле кайткан Гыйният бабай бирә: «Сыер малы кан исен сизеп ярсучан була, авылда кан исе...»* Ә.Зарипов. *Соңрак белгән: мәче җир тетрәвен бер көн алдан сизеп, балаларын таучык башына ташып куйган икән.* Х.Камалов

4) Белеп-аңлап алу; абайлау (сер, ният һ.б.ш.ларны). *Чабышкы Сабан*

*туен алдан сизә.* Мәкаль. *«Яратам» сүзендә Ярмөхәммәт күп мәгънә барын сизде.* Р.Батулла. *Минем иртәгә мәктәпкә килмәскә булуымны да сизде микән әллә?* В.Нуруллин

5) Якынча, чамалап белү; сизенү. *Үз иткәнемне сизәләр. Елан җылыга ияләшкән кебек, миңа гел, иптәш капитан, дип кенә торалар.* Ә.Хәсәнов. *Язганымча, яраганны – ярамаганнан, яманны яхшыдан аеру гына түгел, хурлыкны да бөтен йөрәгем белән сизә торган яшьтә идем инде мин.* Ф.Шәфигуллин. *Сизәм: мин – хәзер сезнең арага кергән артык кеше.* Н.Әминов

**Сизә бару** Вакыт үткән саен ныграк сизү. *Яратуыңны яшәгән саен күбрәк сизә барам.* И.Гази. *Укыган саен, ул үзендә бертөрле уңайсызлык, төшенкелек сизә барды.* А.Алиш. *Авариядән соң үземне көннән-көн гаепле итеп сизә барам шикелле.* Ә.Сафиуллин

**Сизә башлау** Сизү барлыкка килү. *Ярар, бетте бугай дип, кызның гәүдәсен шунда яткан ашъяулык белән япты да, бер-ике генә тамчы кан түгелгән савытны, кеше күрсә сизә башлар дип, йортка чыгарып түкте, аның өстенә кар сипте, аяк белән таптады да яңадан өйгә керде.* Г.Ибраһимов. *Әмма өченче елда инде алар, яшәү яме балада икәнен аңлап, бәхетнең бер ягы китек икәнен сизә башладылар.* Д.Каюмова

**Сизә төшү** Тагын да күбрәк сизү; бераз сизү. *Хәкимҗан уңайсызлык сизә төшеп аңлатты: – Үзең беләсең, Василий, саулык чамалырак бит минем, сугыш инвалиды, нервылар беткән.* Н.Хәсәнов

**Сизеп алу** Бик тиз сизү. *Галимҗан абзый, аңа карау белән, кызның йөрәгендә ниләр кайнаганын бик яхшы сизеп алды.* Ә.Еники. *Шагыйрь җанының үтә дә нечкә, үтә дә яралы кылларын әллә каян сизеп ала бит ул.* Р.Туфитуллова

**Сизеп калу** Сизәргә өлгерү. *Кырын җиргә килеп җиткән трактор тәгәрмәченең дыңгырдап бер таш өстенә килеп менүе булды, рульне кырт борып куйды, һәм фәкать тракторының янтаюын сизеп калды.* Н.Хәсәнов. *Әгәр сизеп калсалар, мине дә, аны да юк итәчәкләр иде.* М.Кәбиров

**Сизеп килү** Күптәннән бирле сизү. *Күптән моны сизеп килә идек инде, ләкин, вакытлы гына чирдер, бер үтер әле, дип ышана идек.* Ә.Еники. *Дания күптән инде үзенең үсештән туктавын сизеп килә.* Ф.Яруллин

**Сизеп тору** Даими рәвештә, һәрдаим сизү. *Җиденче тоемым белән Мәһдиевнең мине үземә караганда да тырышыбрак депутат ясыйсы килүен, шуның өчен барысын да эшләгәнен сизеп торам.* Т.Галиуллин. *Прәннек алырга баруына кадәр сизеп торгач, Хәдичә карчык аның, кермәсә ярар иде, дип кенә әйтүен дә аңлар да рәнҗер төсле тоелды.* М.Кәбиров

**СИЗҮЧӘН** *с.* Сизгер; тиз тоя, сизә торган. *Әгәр дә кыз баланы сак астына алмасаң, хәзер даны ил буйлап җәеләчәген хатын-кыз заты бик тиз сизүчән инде анысы.* Ф.Яхин. *Ә күңел тыныч булмаган җиргә җибәргәндә нидер була, чөнки ана йөрәге алдан сизүчән.* Г.Нәбиуллина

**СИЗҮЧӘНЛЕК** *и.* Сизү үзлеге, тойгысы; сизүчән булу. *Организмнарның теге яки бу рәвешле әйләнә-тирәлек тәэсиренә җавап бирүе ярсынучанлык яки сизүчәнлек (сизгерлек) дип атала.* Биология

**СИКӘЛТӘ** *и.* 1) Юлдагы чокыр-чакыр, тигезсез урын; сикертмә. *Юл сикәлтәләренә җайлашкан машинаның тигез тибрәтүе Рәшидәнең сылу гәүдәсен, һаман саен ныграк якынайтып, куеныма отыры җайлаштыра барды.* К.Кәримов. *Бөгелмәгә кадәрге утыз чакрым араны шулай бардык, юллар ул вакытта сикәлтә, сикерткән саен кырмыскалар кебек бер-беребезгә ныграк ябышабыз, төшеп каласы килми.* Татар әдипләре

2) *күч.* Көндәлек тормышта, эштә һ.б.ш.да очрый торган каршылык, кыенлык, вакытлы уңышсызлык; тормыш авырлыгы. *Әмма 20 ел элек йөрәгендә кабынган сөю уты Нәҗипкә алга таба яшәргә гомер юлларын яктырта, очраган сикәлтә, каршылыкларны җиңәргә көч бирә.* Казан утлары

**СИКӘЛТӘЛЕ** *с.* 1) Сикәлтәсе (*1 мәгъ.*) булган; тигезсез. *Кар япмасы саргая, көпшәкләнә төшкән, юлның кайбер сикәлтәле урыннарында бөтенләй эреп, чүп-чар һәм пычрак арасыннан шәрә урам ташлары калкып чыккан иде.* М.Галәү. *Сикәлтәле карлы юл аларны мөселман зиратына алып килде.* Р.Батулла

2) *күч.* Авыр, мәшәкатьле, каршылыклы. *– Мин андый сикәлтәле сынау юлын исән-имин үттем ич! – дип тынычланырга тырышам.* Ә.Хәсәнов. *Галимлек баскычлары шулай ук шактый сикәлтәле, бормалы, ул үзеңнең бөтен барлыгыңны җигеп эшләүне таләп итә.* Ф.Галимуллин

**СИКЕРГЕЧ** *и.* Ике очына куелган сапларыннан тотып, баш өстеннән һәм аяк астыннан үткәреп әйләндерә торган (астан үткәндә сикереп уздыралар) бау, уенчык һәм спорт әсбабы. – *Ә нәрсә ул сикергеч, Хакимушка? – Скакалка! – диде Хәким җитди генә һәм торып киенә башлады.* З.Хөснияр

**СИКЕРЕШ** *и.* 1) Сикерү (*1, 3, 5, 6 мәгъ.*) хәрәкәте. *Кинәт аның кысык күзләре тагын да кысыла төште, һәм ул арыслан кебек ике сикереш ясады да кувалдадай йодрыгы белән бөтен көченә селтәнеп җибәрде.* Ф.Зыятдинов. *Бүре сикереш ясый...* Р.Батулла. *Кизү бүлмәсендә дә капылт сикереш ясап, түшәмгә туфлие эзен калдырып, һәммәбезне шаккатырды.* Р.Зарипов

2) Сикерү (*2 мәгъ.*) процессы һәм нәтиҗәсе. *Тагын бер ошаган цитата: яшәү – ана карыныннан кабергә озын сикереш кенә.* Безнең гәҗит

3) Сикерү (*1 мәгъ.*) ярышы

4) *күч.* Сыйфат үзгәреше турында: элекке хәлдән яңага кискен күчеш; кискен алга китеш. *Менә шуның нәтиҗәсе буларак, XIX гасырда Европа, рус һәм татар әдәбиятында да өр-яңа тел катламы күтәрелә, жанр һәм тел байлыгы ягыннан яңа бер сикереш ясала.* Р.Низамиев. *Үз гомерендә моңарчы кызлар кулы да тотып карамаган егет өчен бу алга сикереш иде.* З.Хөснияр

5) *күч.* Сөйләгәндә яки уйлаганда бер фикердән, темадан икенчесенә кискен күчеш

**СИКЕРЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) Сикерешләр (*4 мәгъ.*) белән бара торган (иҗтимагый үсеш тур.). *Әйләнеш хәрәкәтләре дә*

*аларның бер ориентациядән икенче ориентациягә сикерешле кучү рәвешендә башкарыла.* Фән һәм тел

2) Вакыты-вакыты белән кискен үзгәрүчән. *Сикерешле рәвештә тиз үскән бик күп илне мисал итеп китерергә була.* Гасырлар авазы

**2.** *и. мәгъ.* Сикерү хәрәкәтләре ясап, сикереп уйный торган уен. *Ни өчен дигәндә, хезмәт хакымның гасыр башыннан бирле артканы юк, ә әйберләргә бәяләр, мин базарга бармый торган арада, бер урында гына тормаганнардыр, сикерешле уйнаганнардыр кебек – күңел сизенә.* Ф.Дәүләтбаев

**СИКЕРТМӘ** *и. к.* **сикәлтә** (*1 мәгъ.*). *Тауның иң югары очыннан аска таба бик каты тизлек белән шуып төшеп китәсең дә, каршы тауга бик зур тизлек белән менеп, сикертмә аша бик ерак, биек сикереп, аягыңда тора алмасаң – егыласың, күздән утлар оча, ди.* Р.Батулла

**СИКЕРТМӘЛӘНҮ** *ф.* Сикертмәлегә (I) әйләнү, сикертмәләр барлыкка килү (юл, аяк асты тур.). *Авылга кайтмаганга бер атна, шул арада юл сикертмәләнеп тә өлгергән.* Казан утлары

**СИКЕРТМӘЛЕ** I *с.* 1) *к.* **сикәлтәле** (*1 мәгъ.*). *Сикертмәле юлдан кайтып та арымаган бит ул, малкай.* И.Нуруллин

2) Чаңгы, чана белән шуып төшкәндә сикертә торган, сикертмәсе булган (тау, калкулык тур.). *Шундый сыйга да, сикертмәле таудан чаңгы шууга да, дус малайларның, кал инде, Булатҗан, дииюләренә дә алданмадым.* Р.Батулла

**СИКЕРТМӘЛЕ** II *с. к.* **сиртмәле**. *Сыйныф ул көнне тулысы белән борынгы татар өен хәтерләтте: чүпләмле сөлге, кабартып сәкегә куелган мендәрләр, сикертмәле бишек.* Д.Бакирова

**СИКЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сикерү** (*1, 2 мәгъ.*)

2) Кулдагы әйберне җиңелчә генә югарыга ыргытып, чөеп алу. *Кызым йомшак уенчыкларын итәгендә сикертә-сикертә уйнап утыра.* Сөембикә

3) Бәреп, кагып югарыга очырту, күтәртү. *Юл бик җайлы түгел шул, сикертә.* А.Хәлим

4) Гәүдәнең берәр өлешен кискен хәрәкәтләндереп, күтәреп кую. *Малайларның, юк дияргә теләп, иңбашы сикертүен өнәмәде шагыйрь.* К.Кәримов. *Сәлимә иңбашларын сикертеп көлде.* Н.Гыйматдинова. – *Балалык ич бу, – диде Мансур, җилкәләрен сикертеп. – Кенәз гамәле түгел.* М.Әмирханов

5) Дыңгырдык юлдан бара торган транспорт нык селкетү, калтырату. *Машина юлда шулкадәр сикерткән: әбине бер алга, бер артка чөеп йөрткән.* Г.Бәширов

6) *з.-сыз* Дыңгырдык юлның яки транспортның нык селкетеп-калтыратып борчуы турында. *Бик сикертә бит, әни... Ни, мин олы мендәремне алырмын, әллә ни булмас.* А.Вергазов

7) Чаптыру (атны һ.б.ны). *Бу сүзсезлек Госманга ошамый, ул атын сикертеп алгарак китә.* Ф. Хөсни

8) *күч.* Сөйләгән, укыган, уйлаган вакытта берәр темага, сүзгә, фикергә һ.б.ш.ларга кагылмыйча, аларны калдырып узу. *Бик калын китап булды шул бу, сикертеп кенә укыдым.* Г.Ахунов. *Гали унынчы сыйныфны сикертеп кенә укыды.* Казан утлары

9) *күч.* Өстәмә мәшәкатьләр, кыенлыклар тудыру; эш-йомыш белән чаптыру; бик нык җәфалау. *Акча күп булу шулай сикертә икән ул.* Безнең гәҗит

10) Аздыру, артыгын кыланырга мөмкинлек бирү

**Сикертә башлау** Сикертергә тотыну. *Ул шкаф өстенә менгән дә йомгакны тәгәрәтә, сикертә башлаган.* С.Сәүбанова. *Машина асфальттан ком-таш юлга борылгач, һәр сикәлтәдә дөбер-шатыр сикертә башлады.* Д.Булатова

**Сикертә бирү** Бернигә карамыйча сикертү; һаман сикертү. *Ә айгыр, елау тавышлары чыгарып кешни-кешни, суккан саен артын сикертә биреп пошкырды, акырды, арткы аякларын күтәреп, һавага типте.* З.Зәйнуллин

**Сикертеп алу** Тиз генә сикертү; аз гына сикертү. *Ләкин абый, нишлим соң, юк бит, дигәндәй, иңнәрен генә сикертеп алды.* Т.Нурмөхәммәтов. *Казандагы танылган бер җырчы шикеллерәк иттереп җилкәләремне дә сикертеп алам, аякларым белән идәнгә дә тибеп куям.* Ф.Латыйфи

**Сикертеп җибәрү** Кинәттән сикертү

**Сикертеп кую** Бер тапкыр сикертү. *Комендант иңнәрен генә сикертеп куйды.* М.Кәбиров. *Биредә кем булмас та, ни булмас дигәндәй, иңнәрен генә сикертеп куйды.* Р.Габделхакова

**Сикертеп тору** Хәзерге вакытта сикертү; даими сикертү. *Көй уңаена иңбашларын да дәртле генә сикертеп тора, җитмәсә.* Ә.Еники

**СИКЕРҮ** *ф.* 1) Көч белән этенеп һәм аякларны баскан җирдән аерып, алга яки югарыга таба кискен ташлану, ыргылу. *Озын-озак уйлап тормады ул, сикереп, балчык койма өстенә менде һәм аз гына баллы җимешләрне, ашыга-ашыга, авызына тутыра башлады.* Ф.Зыятдинов

2) Берәр нәрсә, урын аркылы ыргылып узу. *Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, инде койма аша сикерәм дигәндә генә, төнге куе караңгылыкны ярып, авыл башын машина утлары яктыртты.* Н.Шәрифуллин. *Раян исә, ни затлы булса да, бары табан үбеп ятарга хөкем ителгән мәрмәр баскычларны яшь егетләр сыман җиңел генә сикереп үтеп, үзалдына такмаклый-такмаклый, өскә күтәрелде.* Р.Габделхакова

3) Югарыдан аска табан этенеп һәм аякларны баскан җирдән аерып ыргылып төшү. *Әмма факт – факт булып кала: иң яхшы әзерлекле дип саналган 200 сугышчы фашистлар чолгап алган урынга сикерә.* Ф.Хуҗин. – *Үзең генә ничек кайтасың хәзер?! – дип әйтүем булды, ярдан аерылган басмадан сикерүем булды.* К.Кәримов

4) Җиргә, идәнгә бәрелеп, югарыга күтәрелү. *Аның тубы бик матур иде. Кем белә, бәлки, бөтен Казанда да әле андый матур туп булмагандыр. Аннары, ул бик яхшы сикерә дә иде.* А.Шамов

5) Бер җирдән икенче җиргә ыргылып күчү (ут, ялкын һ.б.ш. тур.). *Саламны тиз арада көчле ялкын камап алды. Ялкын, ярсый-ярсый, кыекка сикерде. Кыекка да ут кабынды.* Ф.Кәрим. *Күпер турысына җитәрәк, алдагы танкның өстенә ялкын сикерә.* И. Гази

6) Нык кагу, көчле тибү (йөрәк тур.). *Сәлимәнең кан тамырлары кайнарланып, йөрәге сикерде.* Н.Гыйматдинова.

*Бу тавыштан аның җанында нindидер кыл өзелгәндәй итте, күз аллары караңгыланды, йөрәге инде күкрәген ташлап чыгардай сикерде.* Казан утлары

7) Кискен үсеп китү (үсемлек тур.). *Арышның сабакка сикерүе*

8) *күч.* Сөйләгәндә, уйлаганда, бер фикердән яки темадан икенчесенә кискен күчү. *Тәрбиясе болай да чамалы булган яңа хуҗаның сабырлыгы шунда төкәнде, кисәк кенә «сез»дән «син»гә сикереп, кызарынып-бүртенеп җикеренә башлады: – Бәлки, сиңа ир дә табып бирергәдер?!* Р.Габделхакова

9) *күч.* Нәрсәнеңдер кыенлыгын күрү, газаплану, интегү. *Тырай тибеп йөрсәң, сикерер көнгә калырсың.* Казан утлары

10) *күч.* Артыгын кылану, узыну. *Күп сикерсәң, бер тотыласың инде ул шулай.* Әкият

◊ **Сикереп төшү** Бик тиз, бик теләп ризалашу, әзер булып тору. *Ректорның бимазаланып чакыруына да сикереп төшү булмады.* Т.Галиуллин

**Сикерә башлау** Сикерергә тотыну. *Аякларын кистермәс өчен, Алып Бәргән сикерә башлады.* Р.Батулла. *Әле генә кулга-кул тотынышып, балалар бакчасындагы кебек әйлән-бәйлән ясаган студентлар басып калган урынnarында заманча бию көйләренә тирбәлә, сикерә башладылар.* Х.Ширмән

**Сикерә бирү** Сикерүен дәвам итү

**Сикереп алу** Бер тапкыр яки кыска вакыт эчендә сикерү. *Аңа бераз гына бензин сибеп, көнләшү уты төртергә кирәк, бер үрле-кырлы сикереп алудан яхшыра гына ул хатын-кыз заты.* Г.Рәхим. *Самат уенчак тай кебек сикереп алды.* Р.Зәйдулла

**Сикереп кую** Кисәк, бер тапкыр сикерү. *Тәгәрмәчләр чокырга туры килде ахрысы, машина бик яман сикереп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Болай уйлаудан йөрәге кинәт сикереп куйды, һәм Хәмит янә эчеп җибәрде.* М.Кәбиров

**Сикереп тору** Озак вакыт дәвамында сикерү; сөйләү моментында сикерү

**СИКЕРҮЛЕ** *с.* 1) Сикереп уйный торган, сикерү хәрәкәте булган (уеннар һ.б.ш. тур.). *Хәзер шәһәрдән әллә ниткән сикерүле бию өйрәнеп кайталар.* М.Мәһдиев. *Хәрәкәтле уеннар үзләре дә йөгерүле, сикерүле, ыргытулы, үрмәләүле һ.б. шундый төрләргә бүленәләр.* Мәгариф

2) Сикерү хәрәкәте, номеры да булган (спорт программасы, ярышы һ.б.ш. тур.). *Академиянең икенче курс студенты – спорт мастеры – ирекле һәм сикерүле гимнастика күнекмәсе буенча чыгыш ясады.* Ватаным Татарстан

**СИКСӘН** *сан* 1) Сигез дистәне эченә алып, 80 санын һәм микъдарын белдерә. *Былтыр урак өстендә сиксән кеше кайтты, бәрәңге алырга да йөздән артык студент җибәрделәр.* Ф.Шәфигуллин. *Сиксән яшьлек мәмләкәтнең оешу тарихын яхшы хәтерләүче ил агалары, ил аналары да исән әле, шөкер.* Р.Батулла

2) *кыек кил. форм., сөйл.* Сиксән яшь. *[Кәримә:] Шул инде. Үзең дә сиксәннең теге ягына чыктың бит.* Д.Салихов

**СИКСӘНЕНЧЕ** *сан* Рәт, тәртип белән санаганда сиксән урынында килә торган тәртип санын белдерә. *Гомернең сиксәненче баскычына аяк басканда да, үзеңдә сабыйлыкның күңел сафлыгын саклый алу – бик кадерле рухи байлык, сирәк очрый торган бәхет ул.* Г.Бәширов. *Ул заманнарда, узган гасырның сиксәненче елларынача, өлкәннәр, авыл агайлары халык турында кайгырта беләләр иде шул.* Ф.Яхин

**СИКСӘНЕШӘР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) сиксән, бертигез күләмдәге сиксән булуны белдергән бүлү саны. *Сиксәнешәр килолы капчыкларны җилтерәтеп йөртә торган хатын әле ул.* Ә.Моталлапов. *Бу әбиләргә, син уйлаганча, алтмыш түгел, җитмеш һәм сиксәнешәр яшь, бик беләсең килсә.* Р.Мөхәммәдиев

**СИКСӘНЛӘП** *сан* Чама белән сиксән; якынча сиксән булуны белдергән чама саны. *Туфанны бирегә китергәндә исә, камерада сиксәнләп тоткын була.* Р.Мостафин. *Бер полк, ягъни мең ярым кешедән без барлыгы сиксәнләп кеше исән калган булып чыктык.* З.Мәхмүди

**СИЛ** *и. гар.* Күпләп кар эрү яки көчле яңгыр яву сәбәпле, таулардан төшә торган көчле, гадәттә, ташлы ташкын. *Кышкы йокыга талыр алдыннан сил акканда елгага керү – үлемгә бару белән бер.* Я.Шәфыйков. *Күз яшьләрем сил булып агадыр. [Чөнки] дөньяның бар михнәтләрен танып белдем.* Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. *Ул елны сил каты акты.* Гасырлар авазы

**СИЛӘ** *и.* 1) Бишек элә торган сыгылмалы агач колга яки тимер пружина. *Җырчы да булмаган әти, Ә миңа бишек siләсен Зыңлап торганын ясарга Өйрәнгән минем әти.* Р.Фәйзуллин. *Элгәре агач силәләр була иде, хәзер пружиналы силәләр эләләр.* Казан утлары

2) *к.* **сиртмә** (*3, 4 мәгъ.*). *Арт яктан тарантас силәсенә кыстырылган чалгы [күренеп тора иде].* С.Рафиков. *Димәк, бу хакта ул колхоз рәисе белән сөйләшкән, чөнки тарантаста рәис кенә йөри, бригадир Бурлы бияне силәгә җигә иде.* М.Хуҗин

**СИЛИКАТ** *и. лат.* **1.** 1) Составында кремнезём булган минералларның гомуми исеме. *Кыздырган вакытта түбән нигезле силикат һәм алюминий кальциты барлыкка килә.* Төзү материаллары

2) Шул минералларны катнаштырып эшләнгән, ясалган нәрсәләрнең гомуми исеме. *Силикат җитештерә торган завод*

**2**. *с. мәгъ.* Шул минералларны катнаштырып эшләнгән, ясалган. *Клуб яңа икән, ул силикат кирпечтән, ике катлы, архитектурасы матур гына.* А.Тимергалин

**СИЛИКАТЛА́У** *ф.* Силикат (*1 мәгъ.*) катнаштыру, составындагы силикат микъдарын арттыру. *Грунтны силикатлау*

**Силикатлап бетерү** Барысын да силикатлау

**Силикатлап кую** Силикатланган хәлгә китерү

**Силикатлап тору** Силикатланган хәлдә тоту, даими рәвештә силикатлау

**Силикатлап чыгу** *к.* **силикатлап бетерү**

**Силикатлый башлау** Силикатларга тотыну

**Силикатлый төшү** Беркадәр силикатлау

**СИЛИКАТЛЫ** *с.* Составында силикат булган, силикат кушылган. *Беректергечләре буенча бетоннар берничә төргә бүленә: цементлы, силикатлы,*

*гипслы һ.б. бетоннар була.* Төзү материаллары. *Силикатлы кирпеч*

**СИЛЛА́БИК** *с. гр. әд.* Басымга нигезләнмәгән, шигырь юлларындагы иҗекләрнең билгеле санда кулланылуына нигезләнгән ритмлы, шундый төзелешле (шигырь системасы тур.). *Силлабик шигырь төзелеше бездә XIX йөзнең ахыры һәм XX йөзнең башында ныклап формалашып җитә.* А.Әхмәдуллин

**СИЛЛА́БИКА** *и. гр. әд.* Шигырьне ритмик берәмлекләргә басым саны яки басым урынына карап түгел, иҗек санына карап бүлү принцибы; иҗек санына нигезләнгән шигырь системасы. *Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы да силлабикага корылган.* Х.Курбатов

**СИЛЛОГИЗМ** *и. гр. лог.* Ике хөкемгә таянып өченчесен (нәтиҗәне) чыгарудан гыйбарәт фикерләү ысулы

**СИЛОС** *и. исп.* Яшел килеш вакланган үсемлек массасын нык тыгызлап, пресслап әчетү юлы белән әзерләнә торган сусыл терлек азыгы. *Берничәсе силос өемен актара торды. Көлкемәзәк әйтеп көлешми, берсен берсе хуш исле кукуруз силосына төртеп аударышмый гына эшләделәр.* З.Вәли

**СИЛОСЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **силослау**. *Сугылган икмәк келәтләргә озатыла. Кукуруз силослана. Игеннән арынган җирләр сөрелә.* Р.Миңнуллин

2) Силоска әйләнү. *Кипкән үләннең агулы үзлеге кими, ә силосланганда бетә.* Агулы үсемлекләр

**Силослана бару** Торган саен ныграк силослану

**Силослана төшү** Бераз силосланган хәлгә килү

**Силосланып бетү** Бөтенләй силосланган хәлгә килү

**Силосланып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп силослану

**СИЛОСЛА́У** *ф.* Силос итү, яшел үсемлек массасын силос өчен әзерләү, силоска эшкәртү. *Быел минә саламны силослау бурычы куелган иде. Ул эшне дә кузгатканнары сизелми.* М.Маликова

**Силослап бетерү** Бөтенләй, тулысынча силослау. *Малга дигән кукурузны да силослап бетерделәр.* М.Әмирханов

**Силослап калу** Нинди дә булса шартларга кадәр силосларга өлгерү

**Силослап куюю** Алдан яки тиз арада силосланган хәлгә китерү

**Силослап тору** Даими яки регуляр рәвештә силослау

**Силослый бару** Рәттән, барысын да силослау

**СИЛОСЛЫ** *с.* Силосы булган; силос салынган. *Силослы траншея. Силослы азык*

**СИЛОСЛЫК** *с.* Силоска ярарлык, силоска дигән. *Силослык көнбагыш массасы. Силослык культуралар*

**СИЛОСӨЛӘШКЕЧ** *и. тех.* Фермаларда силос өләшү машинасы

**СИЛОСТУРАГЫЧ** *и. тех.* Яшел сабакларны турап, башняга яки траншеяга бирә торган машина; *русчасы:* **силосорезка**

**СИЛСИЛӘ** *и. гар.* 1) Чылбыр; тезмә

2) Бер-берсенә бәйләнеп килгән әйберләр җыелмасы, рәт

3) Тарикать имамнарының шәҗәрәсе. *Хәлфә бабайның алар белән бер силсиләдә, суфилык һәм дәрвишлеккә бәйле туганлык һәм бердәмлек оешмасында торуы тарихта билгеле.* Н.Гариф. *Тарикать силсиләсе*

**СИЛСИЛӘНАМӘ** *и. гар.-фар.* 1) Әзлекле тәртиптә ата-баба исемнәре язылган язма, шәҗәрә, нәсел агачы

2) Суфичылыкта остазлык чылбыры

**СИЛУЭТ** *и. фр.* 1) Берәр предметның яки кешенең бер төс өстенә икенче төс белән ясалган яссы сурәте. *Силуэтларны механик юл белән ясаганнар, бу яктан алар капма-каршы нәрсәне яктылык ярдәмендә рәсемгә төшерүне хәтерләтәләр.* Я.Перельман. *Силуэтлар хәзерге фоторәсемнәрне билгеле бер дәрәҗәдә алыштыра алганнар.* Кызыклы физика

2) *кит.* Берәр нәрсәнең караңгыда яки бик еракта күренгән шәүләсе, сызымы, чалымы. *Минә караңгылык эчендә, калкулык өстендә, әрле-бирле йөрүче дошман часовоеның силуэты күренде.* Г.Дәүли. *Мавзолейга кичен бик күп итеп яктылык сибелә. Аның колонналары караңгы күк йөзенә силуэт булып язылалар.* Г.Ахунов

3) Берәр нәрсәнең гомуми формасын билгели торган тышкы сызымы, контуры. *Һәм ул, геометрия күзлегеннән чыгып, теге чибәрнең силуэтын керенке, чыгынкы урыннарын бушлыкта ике кулы белән сызымлап күрсәтте.* М.Мәһдиев

**СИЛУЭТЧЫ** *и.* Силуэтлар ясаучы рәссам

**СИМӘНКЕ** *и. рус сөйл.* 1) Көнбагыш

2) Шул үсемлекнең орлыгы. *Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнке, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде.* Г.Тукай. *Кечерәкләр Үсиядә кипкән балык, симәнке кебекләр белән сәүдә итәргә керешә иде.* Г.Гобәй

**СИМБИО́З** *и. гр.* 1) *биол.* Ике төрле организмның үзара функциональ һәм физиологик яктан бәйле булып яшәве, һәр ике як өчен дә файдалы һәм кирәкле бәйләнештә тереклек итү формасы. *Лишайник – симбиозда яшәүче гөмбә һәм суүсемнән торган бербөтен организм.* Л.Мәүледова. *Хайван белән үсемлек симбиозы. Ике үсемлек симбиозы*

2) *күч.* Тыгыз бәйләнеш, бергәлек. *Гумилёв буенча, гамәлдә я симбиоз турында (бер төбәктә һәрберсе үзенең экологик «почмагын» биләүче ике яки берничә этносның --- янәшә яшәве), яисә химера (төрле этносларның бер үк экологик җирлектә яшәве) турында сөйләргә кирәк.* Т.Кәримов. *Мөселманнар коммунизм, ислам һәм милләтчелек симбиозына ихлас күңелдән ышандылар, үз милли гаскәри частьларын һәм коллегияне шул симбиозны тизләтүче фактор итеп карадылар.* Мирас

**СИ́МВОЛ** *и. гр.* 1) Берәр идеянең, төшенчәнең, күренешнең кабул ителгән шартлы билгесе. *Муса Җәлилнең «Тау чишмәсе» шигырендә чишмә иреккә сусау символы итеп бирелә.* М.Максут. *Символлар борынгы заманнардан ук килә һәм тормышта төрле очракларда кулланыла. Мәсәлән, ай – ялгызлык, сандугач – гүзәллек, чәчәк мәхәббәт символы.* А.Әхмәдуллин

2) Сәнгатьтә: идеяләрне һәм тойгыларны шартлы рәвештә гәүдәләндерә торган образ. *Сак-Сок образын, гадәттә, икесе дә ике якта күрешә алмый газаплanучы якын кешеләр турында сүз барганда, бер чагыштыру, символ*

*буларак телгә алалар.* И.Надиров. *Алдагы юлларда лирик герой белән ай арасында ышанычлы әңгәмә булып ала, символның экспрессив мәгънәсе киңәя төшә.* Т.Галиуллин

3) Нинди дә булса берәмлек, зурлык, матдә һ.б.ш.ның фәндә кабул ителгән шартлы билгесе. *Химик элемент символлары*

4) *информ.* Компьютерда җыелган текстны хасил иткән тамгаларның һәрберсе: аерым бер хәреф, цифр, шартлы билге һ.б.ш. *Серсүз кимендә алты символдан торырга тиеш*

**СИМВОЛИЗМ** *и. фр.* 1) Әдәбият, музыка һәм рәсем сәнгатендә XIX гасырда Франциядә барлыкка килгән һәм Россия, Бельгия, Франциядә иң көчле үсеш алган, чынбарлыкны абстракт һәм шартлы формаларда тасвирлый торган, индивидуализм һәм мистицизм белән сугарылган юнәлеш. *Татар әдәбиятында 1914 елга керү белән символизм җәелеп, көч алып китте һәм Февраль революциясенә кадәр шул көчендә дәвам итте.* Г.Сәгъди. *Прозада символизм принциплары аеруча лирик проза формасында – нәсерләрдә киң чагылыш тапты.* Ф.Бәширов

2) Предметларны билгеләр белән, гомуми төшенчәләрне предметлар белән белдерү күренеше; шуның өчен кулланылган билгеләрнең барысы; символика. *Төсләр символизмы*

3) Әдәбиятта: образлылык

4) Рәсем сәнгатендә: шартлылык

**СИМВО́ЛИК** *с.* 1) Символ функциясен үти торган, символ булып хезмәт итә торган. *Дәрдемәнд кораб символик образы ярдәмендә тарих хәрәкәте, җәмгыятьтәге үзгәреш, туган ил һәм халык язмышы турындагы уйларын гәүдәләндерә.* А.Әхмәдуллин. *Символик сыннар. Символик рәсем*

2) Символ белән белдерелгән, сәнгатьчә шартлы. *Икенче романда мине символик буяулар, мәгънә тирәнлеге һәм логик эзлеклелек сөендерде.* Г.Ахунов. *Шагыйрь тормыш күренешләрен эзлекле сурәтләү юлына төшмичә, символик күзаллауларга таянып, үткәнне, бүгенгене, киләчәкне уртак вакыт төшенчәсенә җыя.* Т.Галиуллин

**СИМВО́ЛИКА** *и. фр.* 1) Берәр нәрсәнең символик мәгънәсе. *Ике башлы бөркет символикасы хәзер Россия гербының төп элементы булып тора.* Татар мифологиясе. *Олимпиада символикасы. Универсиада символикасы. Дәүләт символикасы*

2) Символлар җыелмасы. *«Апрель кызы» шигырьләр җыентыгында экспрессив мәгънә, символика тулып ята.* Г.Ахунов. *Саннар символикасы*

**СИМВОЛИСТ** *и. фр.* Символизм юнәлешендә иҗат итүче, символизм тарафдары. *Яшерен матурлык, идея ачарга омтылып, символистлар ап-ачык нәрсәләрне чиктән тыш катлауландыралар.* М.Гайнуллин. *Символистлар иҗатында музыкага, яңгырашка, авазлар урнашуына зур игътибар бирелә.* Ә.Закирҗанов. *Символизмның пәйда булуын символистлар XX гасыр чигендә хасил булган мәдәни кризис белән бәйлиләр.* Т.Гыйләҗев

**СИМВОЛИ́СТИК** *с.* Символизмга мөнәсәбәтле. *Символистик парчалар*

**СИ́МВОЛЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Символлар белән сурәтләү, гәүдәләндерү. *Әсәрдәге сурәтләр – символик сурәтләр, алар нинди дә булса абстракт идеяләрне символлаштыралар.* Г.Нигъмәти. *Халык җырларында мәхәббәт һәм сабырлыкны, аерылышу һәм хәбәрләшүне символлаштырган бу образлар [ай һәм җил] Такташта мәгънәви һәм экспрессия функцияләрен киңәйтеп кулланылалар.* Т.Галиуллин

2) Символга әйләндерү

**Сиволлаштыра бару** Рәттән, эзлекле рәвештә символлаштыру

**Символлаштырып бетерү** Бөтенләй символ дәрәҗәсенә җиткерү; бик күп символлар куллану

**Символлаштырып тору** Даими яки регуляр рәвештә символлаштыру

**СИМЕЗ** *с.* 1) Йомры, юан, калын; тулы гәүдәле (кеше тур.). *Бары шуннан соң гына базар башының симез йөзендә ягымлылык чаткылары күренә башлады.* Н.Фәттах. *Фәтхулланың саллы алтын балдак белән авырайган симез бармагы һава сөздө.* А.Гыйләҗев

2) Мае күп, бик майлы (ит тур.). *Күп һәм симез ит белән озак кайнаган бу шулпа бик көчле, бик тәмле, бик туклыклы иде.* Г.Ибраһимов. *Симез билдәмә итен табынга кайнар килеш бирәләр.* Ю.Әхмәтҗанов

3) Тәнендә мае күп булган; көр (терлек, кош-корт тур.). *Билдәмә артыннан симез каз белән симез үрдәк, аннан бәлеш, иң ахырдан никах ширбәте килде.* Г.Ибраһимов. *Атна үтмәде, симез генә тәкә суеп, хатыныннан казан астырды Нурислам.* М.Кәрим

4) Гумуска бай булган, черемәле, уңдырышлы. *Кибән башларыннан озын саламнар буенча авыр, салмак кына тамган тамчылар, көзнең күңелсез җырын җырлагандай, тып-тып итеп, симез җиргә тамалар.* Һ.Такташ. *Бу – җирнең симез урыныдыр: монда көпшәк гөмбәләрен калкытып «җир мае» үсә.* К.Кәримов

5) Тулы, тук (башак тур); итләч (җиләк-җимеш һ.б.ш. тур.). *Йодрыктан зур симез һәм татлы каражимеш, кытай алмасыдай эре, ләкин хуш исле чия ашагандай булам.* Г.Кутуй. *Мондый тәмле пәрәмәчләрне, мондый симез помидорларны, сап-сары йомыркаларны, мондый тәмле каймакны аның гомерендә дә ашаганы булмагандыр, мөгаен.* Ф.Бәйрәмова

6) Тутырылган, тыгыз, бүртеп, кабарып торган. *Шуннан соң ул кесәсеннән симез янчык чыгарып, бездәге илленче еллардагы заем кәгазе хәтле акча сайлап алды һәм җилпенүдән туктаган кәләпүшемә салды.* К.Кәримов

7) *күч.* Куе кара, куе буяу белән ясалган; гадәтидән зуррак итеп ясалган, сызылган һ.б.ш. *Хәлим ишектәге тамганы сызып бетерде дә, канат очын бөтерә-бөтерә, тәре сызыклары тоташкан урынга симез нокта төртте.* Г.Гыйльманов

8) *күч.* Җитеш тормышлы, бай, барлыклы. *Революциядән соң хакимиятне үз кулларына эләктерүчеләр (байларны күрәлмаучылар!) ә дигәнче үзләре дә симез байларга әвереләләр.* З.Солтанова

◊ **Симез калҗа** Җиңел генә килгән зур акча, әйбәт табыш; төшемле эш һ.б.ш. турында; майлы калҗа. *Беребез дә пирамиданың түбәсенә – симез*

*хөкүмәт калҗасы бүленә торган урынга менеп җитә алмады.* Т.Галиуллин

**СИМЕЗЛЕК** *и.* 1) Артык симез булу хәле (кеше тур.). *Ханымның йөзе ярыйсы гына чибәр булса да, артык симезлек кыяфәтен боза.* Ш.Усманов

2) Симез булу сыйфаты һәм дәрәҗәсе (тән төзелеше, ит, хайван тур.). *Үзенең симезлеге белән аерылып торган кысыр сарыкка чират җиткәч, һәрвакыт аның кәефе китеп бара.* М.Шабай

3) Уңдырышлылык (туфрак тур.)

4) *күч.* Көрлек, барлык, муллык

◊ **Симезлегенә чыдый (чыдаша) алмау** Байлыктан я дәрәҗәдән файдаланып масаю, үсенү, артыгын кылану турында. *Гали укыр өчен түгел, байлыкка, симезлеккә чыдаша алмаганнан гына йөри инде.* Г.Ибраһимов. *Әле менә күптән түгел генә Индонезия утрауларында байлыкларына, симезлекләренә чыдый алмый кызынып ятучыларны көчле дулкын океанга сыпырып төшерде.* Безнең гәҗит

**СИМЕРТҮ** *ф. йокл. юн.* 1) Симезгә әйләндерү, симез итү; симерүгә сәбәп булу. *Инҗирне гарәпләр тин дип әйтәләр. Туклыклылыгы башка җимешләрдән артыграк, гәүдәне симертә.* Мирас. *Эш шунда: еш кына бәрәңгене симертә, диләр.* Мәдәни җомга

2) Сугымга әзерләп ашату. *Хатыны Нәзифә белән бергәләп, яшь үгезләрне симертәләр икән. Колхозга ел саен 200 баш үгез симертеп бирәләр.* Г.Ахунов. *Кыш кердеме, янә ял юк – муеннан эш: терлек-мазар симерт, илтеп сат, янә абзар тутырып мал-туар ал.* М.Хәсәнов

3) *з.-сыз* Симез итү турында. *Ипиләре дә ничә еллар – кәлҗемә: алабута ашаганнан соң хәтәр симертә бит, Хәдичәкәем!* Р.Гаязетдин

4) *күч.* Рәхәт, иркен тормыш тәэмин итү, муллыкта яшәтү; ялкауланырга һ.б.ш. мөмкинлек бирү, юл кую

**Симертә башлау** Симертергә тотыну. *Казанга терәлеп торган орденлы совхозларның берсендә куе сыер сөте эчертеп кенә биш дәнә чучка малаен симертә башладылар.* А.Гыйләҗев

**Симертә төшү** Бераз симертү; беркадәр симергән хәлгә китерү

**Симертеп бетерү** Барсын да симертү

**Симертеп кую** Алдан ук симертү. *Сарыкларны махсус корбан гаетенә симертеп куялар, бәйрәмгә ике ай вакыт калгач, ныклап ашаталар.* Ватаным Татарстан

**Симертеп тору** Һәрвакыт симертү, даими рәвештә симертү

**Симертеп яту** *сөйл. к.* **симертеп тору**. *Хәлил Хәсәнович үз куенында кара елан симертеп ятканлыгын аңлагач, инде кешеләрне таный белмәвен дә төшенергә тиеш иде.* Ф.Яхин. --- *бюрократлар аппаратын симертеп ятабыз. Нишләп симертеп ятабыз? Чөнки алар – илебезнең йөзе, һәм бу йөз шома булырга тиеш.* А.Костюшкин

**СИМЕРҮ** *ф.* 1) Тәнгә май җыелып, симезгә әйләнү, симез (*2, 3 мәгъ.*) хәлгә килү. *Эт симерсә, иясен тешли.* Мәкаль. *Җәй җәйләгән, көзге уҗымнарда симергән, инде башмак танага әверелеп килә торган бу бозау шактый көч җыйган.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Бай, рәхәт тормышта яшәп азу, артыгын кылану. *Бүгенге симерүе генә җитмәгән, илгә-халыкка андыймондый авыр көннәр кичерергә туры килсә, бу анда да корсагын шиңдерәсе түгел.* Р.Төхфәтуллин. *Үләнле җирдә – үгез, үлекле җирдә – мулла, даулы җирдә түрә симерә, сахрада безнең кебек муллалар булмаса, сезнең – җебек җаһилләрнең башын эт кимерә!* Р.Батулла

**Симерә бару** Вакыт узган саен ныграк симерү. *Кави үсә, симерә барды һәм иясен – остазын тешли башлады.* Р.Батулла. *Тиз үстеләр, көн узган саен симерә барды чучкалары.* Н.Таҗиев

**Симерә башлау** Симерү ягына үзгәрү. *– Минем гаскәрем тик торып ялыкты, атлар симерә башлады, меңбашлары үзләренең сәләтен күрсәтәлми күңелсезләнә, – дигән.* З.Мурсиев

**Симерә тору** Ниндидер процесс беткәнче, шул процесс белән берьюлы симерү. --- *провинциаль «бароннар», җирле олигархлар – барысы да мәшһүр «савымчылар». Халыктан алар бау ишәләр һәм һич аямыйча тиресен каезлыйлар. Үзләре, табигый, симерә торалар.* Ватаным Татарстан

**Симерә төшү** Бераз симерү; тагын да ныграк симерү

**Симереп бетү** Нык симерү, тәмам симезгә әйләнү. *Таймас: «Симереп бетәм инде!» – дип, корсагына шапылдатып карады.* А.Тимергалин

**Симереп җитү** Тиешле дәрәҗәдә, җитәрлек симерү. --- *малларның да чырае юк: җәй уртасы җитсә дә, Якты Күлдәге кебек симереп җитмәгәннәр, кайбер тайлар әле һаман да ябагаларын коеп, матурланып китә алмаганнар.* Г.Ибраһимов

**Симереп китү** Тиз арада симерү. *Гәүдәсенең артык калынаеп, тәненең симереп китүенә сәбәп шул хәрәкәт азлыгы булмадымы икән.* Казан утлары. --- *Рональд Пост, артык симереп китү сәбәпле, хөкем карарын гамәлгә ашыру вакытын кичектереп торуларын сораган.* Татарстан яшьләре

**Симереп яту** Гел симерүдә генә булу. --- *эшсезлектән симереп яткан Зәмзәмбикә нахак сүзләре белән бик нык теңкәгә тиде, канына бик күп тоз салды.* М.Хәсәнов

**СИМЕРҮЧӘН** *с.* Бик тиз, бик җиңел симерә торган. *Яшь мал тиз симерүчән була*

**СИМИЯ** *и. гар.* Алхимиягә нигезләнгән гыйлем, магия. *Хи, хи, хи, гыйльме симия башка ул, мәсәлән, гыйльме шәригать – башка.* Ф.Әмирхан. *Симия гыйлеме ярдәмендә кибәкне хәлвәгә әверелдерә алучы Әбүгалисиналарга алмашка --- гап-гади сәүдәгәр, мулла, шәкерт, гап-гади татар кызы һ.б. реаль типлар килде.* И.Нуруллин

**СИММЕ́ТРИК** *с. к.* **симметрияле**. *Монда – «Бүзләрем мана алмадым» шигырендә – Дәрдемәнд строфалар арасында симметрик бертөслелекне җимерә.* Х.Госман

**СИММЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Нәрсәнең дә булса өлешләре үзәккә карата тигез ераклыкта тору күренеше; бербөтенне тәшкил итә торган нәрсәләрнең урнашу тәртибендәге пропорциональлек, тигезлек. *Көмеш чәнечкеләрне тагы да күчеребрәк, симметрия саклабрак рәтләде.* М.Мәһдиев

**СИММЕ́ТРИЯЛЕ** *с.* Төзелеше, формасы белән симметриягә нигезләнгән.

*Ул – математик кеше, аларның (чәчәкләрнең) ифрат төзек, циркуль белән сызган кебек симметрияле булуларына гына игътибар итте.* А.Тимергалин

**СИМПА́ТИЯ** *и. гр.* Кемгә дә булса уңай мөнәсәбәт, аны ошатып, яратып кабул итү, үз итү, күңел тартылу. *Кызның барлык кыяфәте --- бик борынгы һөнәр булган төзүче һөнәренең иясенә симпатиябезне көчәйтә.* Г.Ахунов. --- *моннан авторның симпатиясе үз кул көчләре белән бәхет эзләүчеләр ягында икәнлеген аңлыйбыз.* М.Мөхәммәдиев

**СИМПО́ЗИУМ** *и. лат.* Нинди дә булса махсус (ешрак фәнни) мәсьәләгә, темага багышлап үткәрелә торган зур киңәшмә. *Тул-тулы бер китап багышлаганнар аңа, симпозиум нәтиҗәләрендәге фикерләрне берләштереп.* Ф.Баттал

**СИМПТОМ** *и. гр.* 1) *мед.* Берәр төрле физик яки рухи халәтнең (чир, кичереш, курку һ.б.ш.) тышкы чагылышы, күзәтеп була торган билгесе. *Ул аңгы-миңге хәлдә көчкә генә тын алып ята. Сулышы гыжылдап чыга иде. Бу инде – бик начар симптом.* Х.Камалов. *Авыруның беренче симптомнары*

2) *күч.* Берәр тенденциянең, күренешнең, үзгәрешнең сизелерлек билгесе. *Минем күңелемдә шигърият үлә башлады, ә бу хәл, мин үземнән беләм, бик хәтәр симптом.* М.Мәһдиев. --- *һаман бер үк җавап ишетәм: язылган законнар өстен, диләр. Бу үзе үк – куркыныч симптом. Дөньяда беркайчан да язылган законнар язылмаган законнардан өстен була алмый.* Т.Миңнуллин

**СИМПТОМА́ТИКА** *и. гр. мед.* Барлык симптомнар, шуларны бергә караганда барлыкка килгән тулы картина

**СИМСИМ** *и. гар.* Мае өчен күп кенә субтропик һәм тропик регионнарда игелә торган культуралы үсемлек, һинд көнҗете. *Ибне Фазлан әйтәдер: «Болгарларда балык маеннан башка май юк. Алар аны зәйтүн мае вә симсим мае урынына тоталар».* Г.Әхмәрев

**СИМУЛЯНТ** *и. лат.* Авыру булып кыланучы, авыруга сабышучы, булмаган авыруын яки аның аерым симптомын бар дип күрсәтүче. *Фәнис: «Әллә мин симулянтмы, больницага керергә тормыйм әле», – диде.* Ф.Яруллин. *Ул акылдан язган кеше булып кыланды. Суд-психиатрия экспертизасы моның ялган икәнлеген, Волынкинның симулянт икәнен ачыклады.* Т.Нәҗмиев

**СИМУЛЯНТЛАНУ** *ф.* Симулянтлык эшләү; симулянт булып кылану

**Симулянтлана төшү** Бераз симулянтлану

**Симулянтланып бетү** Бөтенләй симулянтлану, тәмам симулянтка әйләнү

**Симулянтланып йөрү** Еш кына симулянтлану

**СИМУЛЯНТЛЫК** *и.* Симулянт кыланышлары; симулянт булу. *Прогулчылыкка, симулянтлыкка, хуҗасызлык, плансызлыкка каршы көрәш ударниклар әдәбиятында общий фразалар белән кизәнүдән генә тормый.* М.Җәлил. *Көнбатыш Украинадан килгәннәр симулянтлыклары белән теңкәгә тиде.* Х.Камалов

**СИМУЛЯТОР** *и. лат.* 1) *иск.* Симулянт

2) Берәр транспорт чарасы яки аппарат белән идарә итү күнекмәләре бирү өчен ясалган механик җайланма яки компьютер

**СИМУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Алдау максаты белән берәр нәрсә турында ялгыш фикер тудырырга тырышу; симулянтлану күренеше

**СИМФО́НИК** *с. муз.* 1) Музыкаль форма буларак симфония белән бәйле, симфониягә караган. *Өстәвенә җәй көннәре шәһәр бакчасында 25 кешелек симфоник оркестр концертлар бирә торган була.* Г.Ахунов

2) Кыллы, тынлы һәм бәрмә уен коралларыннан торган оркестр башкаруы өчен билгеләнгән. *Бары тик Фәрит Яруллинның «Шүрәле»сен һәм Фасил Әхмәтовның Фәрит Яруллинга багышланган симфоник поэмасын тыңлаганда дөньямны онытам.* Т.Миңнуллин

**СИМФО́НИЯ** *и. гр.* 1) *муз.* Оркестр өчен язылган, гадәттә дүрт өлештән торган күләмле музыкаль әсәр. *Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый.* Г.Кутуй. *Һади Такташның шигырьләренә симфония язарга мөмкин, ләкин җыр түгел.* Х.Курбатов

2) *күч.* Төрле тавыш, төс яки тоннарның гармоник кушылуы. *Флейталар тына, минем даулы йөрәгем симфониясен тыңлап*... Ә.Фәйзи. *Куе тәэсир, талантлы шатлык, меңнәр тавышы, төзү симфониясе бер генә кешенең күңеленә сыймый.* Г.Кутуй

**СИН** *а.* (синең, сиңа, сине, синнән, синдә) 1) Берәр кешенең үзенә турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә, шул кешегә күрсәтә торган зат алмашлыгы. *Мине утка аткан ул – син, Мине суга салган да – син, Утта янсам, суга батсам, Тартып алган аллам да – син.* С.Рәмиев. *Зөфәр абый мине, ишарәләп, үз янына чакырды: – Менә кил әле, син бәләкәй малай түгел бит инде, – диде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Билгесез ияле яки гомумиләштерелгән мәгънәле җөмләләрдә гомумән кешене белдерә. *Бездә бит шундый бер гадәт бар: әгәр син үз эшеңне тавыш-гаугасыз әйбәт эшләп йөрисең икән, сине күрмиләр.* Ф.Яруллин. *Кесә төбеңдә ачкыч булмаса, шәһәр өчен син кунак түгел, ятим килмешәк кенә икәнсең.* К.Кәримов

◊ **Син бел дә мин бел** «Бу сүз синең белән ике арада гына сер булып калсын» дигән мәгънәдә кисәтеп әйтү сүзе. *Сөт турында син бел дә мин бел. Суяр өчен кайтарылган бу сыерлардан сөт-май да алу мөмкинлеге хуҗаларның планына кермәгән иде күрәсең.* М.Әмир. **Син генә башлы, бүтәннәр көйгән кашлы** *мыск.* Акыл сатарга яратучыга карата әйтелә. *Һи! Син генә башлы, бүтәннәр көйгән кашлы, ә?!* Б.Камалов. **Син дигәндә башым идәндә** «Баш орып хезмәтеңә әзермен» дигән мәгънәдә әйтелә. **Син дә мин, Мөхәммәтәмин** «Без икебез генә, башка беркем дә юк» дигән мәгънәдә (берәр эшне башкару тур.). *Әллә кем ясамый ич аны – син дә мин, Мөхәммәтәмин.* А.Расих. *Актив бер уч кеше ул: син дә мин, Мөхәммәтәмин.* Ф.Хөсни. **Син ишетмә, мин күрмим** Берәр яшерен эштәге кешеләрнең бер-береннән белмәмешкә салышырга сүз бирешкән әйтемнәре. *Син ишетмә, мин күрмим: тегеләр тыштан бер-беренә дошман булып йөрсәләр дә, астан барышып*

*йөриләр икән.* Н.Исәнбәт. **Син күр дә мин күр** Тиз арада, кеше-кара күргәнче. *Ялт бер заман, атка да сикереп менде, чи-и итеп бер сызгырды, син күр дә мин күр: урман эчләп чабып та китте, ди.* Н.Исәнбәт. *Шуннан, син күр дә мин күр. Уразмәт карт кинәт баеп киткән.* Ә.Фәйзи. **Син сандугач, мин карлыгач** Пар килгән, бик тату, сөйләшеп туймый торган кешеләр турында. **Син сорама, мин әйтмим** 1) Я мактап бетергесез шәп, я телгә алгысыз дәрәҗәдә түбән нәрсә хакында сөйләгәндә әйтелә. *Бездә шундый бер корал бар хәзер. Ул шундый кыра, син сорама, мин әйтмим! Менә ишетерсең әле.* Г.Бәширов. *Ул Хафизларның Шәмсебәдәрләре дә инде, син сорама, мин әйтмим, ничәнче киявен ташлап, атасына кайта.* Н.Исәнбәт; 2) Нәрсәнедер әйтәсе, аңлатасы килмәгәндә әйтелә. *Аны мин сиңа үзем алып киләм. Ә каян һәм ничек алачагымны син сорама, мин әйтмим.* В.Нуруллин

**СИНАГО́ГА** *и. гр.* 1) Яһүдиләр гыйбадәтханәсе. *Мәчет, чиркәү, костёл, синагога ише биналарның бер-берсе белән бәрелешкәне юк, ә аларны тотучы руханиларның үзара маңгайга маңгай килүе байтак булган.* З.Мансуров. *1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә башкаланың Поклонный тавында православие чиркәве һәм синагога белән рәттән мәчет тә төзелде.* Я.Шәфыйков

2) Яһүдиләрнең дини җәмәгате

**СИНГАРМОНИ́ЗМ** *и. гр. лингв.* Кайбер телләрдә бер сүз кысаларында авазларның (ешрак сузыклар һәм кайбер очракларда тартыкларның) берничә фонетик билгесе буенча охшаш булуы. *Сингармонизм, яки сузыклар гармониясе – барлык төрки телләр өчен дә диярлек (чуваш һәм үзбәк телләреннән башка) характерлы билге.* Татар грамматикасы. *Татар әдәби теленең үз сүзләрендә һәрвакыт диярлек сингармонизм саклана.* Х.Сәлимов. *Сингармонизм законы агглютинатив системадагы төрки, монгол һ.б. телләргә хас.* Ф.Сафиуллина

**СИНГАРМО́НИК** *с. лингв.* Сингармониягә нигезләнгән, шуңа нисбәтле. *Сингармоник модельләр сузыкларның рәте (аңкау гармониясе) һәм иренләшүе (ирен гармониясе) белән билгеләнә. Татар телендә дүрт сингармоник модель аерып чыгарырга була.* Татар грамматикасы. *Сингармоник параллельләр*

**СИНДИКАЛИЗМ** *и. фр. тар.* Эшчеләр хәрәкәтендә сәяси көрәш зарурлыгын кире кагып, профсоюзларның әһәмиятен өстен күрә, икътисади көрәш алып баруны гына таный торган агым

**СИНДИКАЛИСТ** *и. рус* Синдикализм тарафдары

**СИНДИКАЛИ́СТИК** *с.* Синдикализмга мөнәсәбәтле. *Синдикалистик карашлар*

**СИНДИКАТ** *и лат. икът.* 1) Бер тармакка караган мөстәкыйль предприятиеләрнең үз товарларын бер челтәр аша сату өчен төзелгән зур берләшмәсе. *Зур-зур синдикатлар барлыкка килү*

2) Берничә сәнәгать, финанс яки башка предприятиенең берәр зур эш өчен төзегән кыска вакытлы берләшмәсе

3) Кайбер илләрдә: профсоюз

4) *тар.* СССРда XX гасырның 20 нче еллары ахырына кадәр сәнәгать тармагындагы берничә трестны берләштергән хуҗалык оешмасы

**СИНДИКАТЧЫ** *и.* Синдикат (*1, 2 мәгъ.*) әгъзасы, аны оештыручы. *Нефть синдикатчылары*

**СИНЕ́КДОХА** *и. гр. әд.* Бер предметның сыйфатын икенчесенә күчерүдән гыйбарәт метонимия төре: предмет урынына аның берәр аерым кисәген атау, күплек урынына берлек санын куллану кебек стилистик алым, сәнгатьчә троп. *Телдә синекдохалар күп кулланыла: «безгә дә көн килер» дибез икән, «безгә дә көткән чор килер» дигәнне аңлыйбыз.* Әдәбият белеме

**СИНКО́ПА** *и. гр.* 1) *муз.* Ритмны кискенләштерү, җанландыру өчен, музыкаль басымны тактның көчле өлешеннән көчсез өлешенә күчерү күренеше

2) *лингв.* Сүз уртасындагы аваз яки авазларның төшеп калу күренеше

**СИНКРЕТИЗМ** *и. гр. кит.* 1) Берәр күренешнең башлангыч чорында мөстәкыйль рәтләргә бүленмәгәнлеге, тармакланмаганлык хәле һәм күренеше. *Беренчел культурага синкретизм хас. Шушы сыйфат фикерләү рәвеше белән идеологиядә дә урын алган.* Г.Дәүләтшин

2) Берничә сәнгать төренең бербөтенлектә чагылуы. *Борынгы заманнарда сикретизм хөкем сөргән, ягъни шигъри сүз, музыка, бию һ.б. сәнгать төрләре, үзара тыгыз керешкән булып, бер-бере белән аерылгысыз бәйләнештә башкарылган.* А.Әхмәдуллин. *Югарыда сүз алып барылган Ф.Туйкин иҗатына да синкретизм хас.* Ә.Закирҗанов

3) *филос.* Философия һәм диннәр тарихында эклектизмның бергә кушылуы мөмкин булмаган төрле карашларны механик рәвештә бергә кушудан гыйбарәт бер төре

**СИНКРЕ́ТИК** *с. кит.* Синкретизмга нигезләнгән. *Синкретик сәнгать бигрәк тә халык иҗатында озак дәверләр буена яшәп килә.* Т.Галиуллин. *Ул чор әдәбияты [Алтын Урда] синкретик характерда булганлыктан, әдәби әсәр аша шул дәвер зыялысының фәлсәфи аң дәрҗәсе, галәм турындагы төшенчәләре --- хакында да фикер йөртергә мөмкин.* Н.Хисамов

**СИНКРЕТИСТ** *и. гр. кит.* Синкретизм тарафдары

**СИНОД** *и. гр.* 1) *тар.* 1917 елга кадәр Россиядә рус православие чиркәвенең иң югары коллегиаль органы. *Россия буенча гомумхристианлаштыру эшләре белән Синод җитәкчелек итә.* Г.Исхакый. *1749 елның 29 сентябрендә Синод, бу мәсьәләне тизләтү чараларын күрмәгәне өчен, губернаторга кисәтү ясый ---.* М.Гайнетдинов

2) Хәзерге Россиядә рус православие чиркәве патриархы каршындагы киңәш бирү хокукы булган орган

**СИНО́ЛОГ** *и. лат.* Кытай теле, әдәбияты, тарихы, мәдәнияте белгече. *Безгә Кытай чыганакларында татар этнонимының дада, тата рәвешендә аталуы хакында синологларның хезмәтләре аркылы билгеле.* М.Әхмәтҗанов. *Шул галимнәрнең берсе – танылган әдип һәм синолог Үткер Абдурәхим.* М.Ерзин

**СИНОЛО́ГИК** *с.* Синологиягә караган. *Синологик тикшеренүләр*

**СИНОЛО́ГИЯ** *и. лат.* Кытайны, кытай телен һәм әдәбиятын өйрәнә торган фәннәрнең җыелмасы

**СИНО́НИМ** *и. гр. лингв.* **1.** Төшенчә һәм мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән, аваз составы исә үзгә булган сүз, идиома һ.б.ш. *Туган телнең синонимнарын яхшы белгән кеше үз фикерләрен төгәлрәк һәм матуррак белдерә ала.* Ф.Сафиуллина. *Ана теленең тирән сандык төпләреннән үзеңә кирәкле сүзләрне актарып чыгарасың, дистәләрчә синонимнардан нәкъ шул урынга утырдаен сайлап аласың.* К.Миңлебаев

**2.** *с. мәгъ.* Мәгънәдәш, синонимик. *Тикшерелгән әсәрләрдә зур күпчелекне фразеологизмнардагы синоним вариантлар тәшкил итүе мәгълүм булды.* Д.Рамазанова. *Бу атама оригиналда Господь, Бог, Владыко дигән синоним парлары белән бирелә һәм әлеге сүзләр белән күптөрле сүзтезмәләр барлыкка китерелә.* И.Бәширова

**СИНОНИ́МИК** *с.* 1) Мәгънәдәш, охшаш яки бер үк мәгънәле. *Еш кына алар башка сүзләр белән синонимик мөнәсәбәткә керәләр: вату-җимерү; вату-сындыру; вәгазь-нәсыйхәт һ.б.* Ф.Сафиуллина

2) Синонимнардан (*1 мәгъ*) торган, шуларны эченә алган. *Синонимик оялар алынма сүзләр исәбенә дә байый.* Ф.Сафиуллина. *Төрки телләр, шул исәптән татар теле дә, --- Көнбатыш Европа телләреннән меңләгән сүзләр кабул иткән, һәм шуның нәтиҗәсендә бик бай синонимик рәтләр барлыкка килә.* Ш.Ханбикова

3) Синонимлыкка, синонимия күренешенә караган; синонимикага мөнәсәбәтле. *Телнең синонимик байлыгыннан файдалана белү сүз белән эш итүче белгечләргә бик кирәк.* Ф.Сафиуллина. *Сүзләрнең синонимик мөнәсәбәтләре кайвакыт катлауланып китә.* Хәзерге татар әдәби теле

**СИНОНИ́МИКА** *и. гр. лингв.* 1) Тел белеменең синонимнарны өйрәнә торган тармагы

2) *җый.* Телнең барлык синонимнары, синонимнар байлыгы

**СИНОНИ́МИЯ** *и. гр. лингв.* Сүз, фразеологизм, җөмлә һ.б.ш. тел берәмлекләренең бер үк мәгънәне белдерү күренеше, мәгънәдәшлек

**СИНО́НИМЛАШУ** *ф.* Синонимнар булып китү; синонимик мөнәсәбәткә керү. *Вакытлар үтү белән, сүзләрнең синоним парлары булмаганнары синонимлашырга, яңа синоним парлар барлыкка килергә мөмкин.* Ш.Ханбикова

**Синонимлаша башлау** Синонимик мәгънәләре ачык сизелү

**СИНО́НИМЛЫК** *и.* Синоним булу күренеше, хәле. *Синонимлыкны билгеләүдә дә сүзләрнең бер-берсен алмаштыра алулары нигез билгеләрдән санала.* Ш.Ханбикова. *Бер чорда синоним итеп кулланылган сүзләр, вакытлар үтү белән, синонимлыкларын югалтырга да мөмкин.* Хәзерге татар әдәби теле

**СИНО́ПСИС** *и. гр. кит.* 1) Бер үк мәсьәләгә кагылган материаллар, мәкаләләр җыентыгы

2) Берәр нәрсәнең эчтәлеген, мәгънәсен гомумиләштереп чагылдырган кыскача өземтә

**СИНО́ПТИК** I *и. гр.* Һава хәлен күзәтү һәм билгеләү хезмәтендә эшләүче, синоптика белгече. *Һм-м, кара син аны, мин сиңа синоптик түгел бит кайсы көнне нинди һава торышы көтеләсен әйтергә.* Ф.Дәүләтбаев. *Син нәрсә, колакка катымы соң? Синоптик, дим, һава торышын әйтүчеләрне шулай атыйлар.* Аманулла

**СИНО́ПТИК** II *с.* Синоптикага мөнәсәбәтле. *Соңгы вакытта синоптик метеорология динамик метеорология белән бик нык якынайды.* Физик география. *Синоптик мәгълүмат. Синоптик карта*

**СИНО́ПТИКА** *и. гр. махс.* Метеорологиянең Җир атмосферасында барган, киләчәктә һава торышына тәэсир иткән физик процессларны өйрәнә торган тармагы

**СИНО́ПТИКЛЫК** *и.* Синоптик һөнәре һәм хезмәте. *Бик күп еллар синоптиклыкка укыган берәү туган авылына кайтырга чыккан, ди.* Г.Бәширов

**СИНТА́ГМА** *и. гр. лингв.* Сөйләмнең бер фраза басымы белән әйтелә, интонация һәм мәгънә ягыннан бербөтен тәшкил итә торган, бер яки берничә сүздән төзелгән синтаксик берәмлеге. *Татар сөйләмен синтагмаларга бүлгәндә, мелодика, темп һәм пауза актив катнаша.* Х.Сәлимов

**СИНТА́КСИК** *с. лингв.* Синтаксис белән бәйле, синтаксиска мөнәсәбәтле. *Абсолют синонимнарны ярдәмлекләрдә дә, кушымчаларда да, хәтта синтаксик конструкцияләрдә дә табабыз.* Ш.Ханбикова

**СИ́НТАКСИС** *и. гр. лингв.* Тел белеменең җөмләләрне, сүзтезмәләрне, җөмлә кисәкләренең үзара бәйләнеш ысулларын, чараларын өйрәнә торган тармагы. *Зәкиевнең төп фәнни эшчәнлеге синтаксис белән бәйле.* И.Бәширова

**СИНТАКСИСТ** *и. рус* Синтаксис белгече. *Зәкиев, иң беренче чиратта, синтаксист галим.* Г.Нәбиуллина

**СИ́НТЕЗ** *и. гр.* 1) Фәнни тикшеренүнең аерым хөкемнәргә нигезләнеп, төп, гомуми билгеләрне ачыклаудан гыйбарәт булган бер ысулы: төп принципларданн нәтиҗәләр чыгару һәм өйрәнү алымы; *киресе:* **анализ** // Объектны аның барлык бәйләнешләре белән бергә эзлекле рәвештә тасвирлау алымы

2) *кит.* Кушу-берләштерү, гомумиләштерү күренеше һәм нәтиҗәсе. *Әдәби әсәрнең теле төрле стилистик катламнар синтезыннан гыйбарәт.* М.Мөхәммәдиев. *Димәк, фәнни фантастика хыял һәм чынбарлыкның кушылуы гына түгел, ул бер үк вакытта сәнгатьле һәм фәнни фикерләрнең аерылмас синтезы да икән.* Р.Кукушкин

3) *хим.* Гади матдәләрнең тәэсир итешүләре нәтиҗәсендә катлаулырак кушылма хасил булу күренеше һәм нәтиҗәсе. *Башта кандидатлык, аннан докторлык диссертациясен яклагач, каталитик синтез лабораториясен ачтым.* Р.Вәлиев. *М.А. Бутлеров каучук сыйфатында кулланыла торган изобутилен синтезын эшли.* Төзү материаллары

4) *мат.* Билгеледән билгесезгә, бирелгәннән эзләнә торган зурлыкка таба фикер йөртү яки исбатлау методы

5) *әд.* Гомумиләштерү, типиклаштыру күренеше (әдәбиятта һәм сәнгатьтә). *Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң» әсәре – шигырь белән язылган роман. С.Хәким аны оста корылган конфликтлы поэмаларның синтезы буларак*

*бәяли.* Т.Галиуллин. *Экран синтезы исә (кино, телевидение һ.б.) чынбарлыкны тагын да киңрәк, тулырак колачлап, комплексы чагылдырырга омтыла.* Әдәбият белеме

**СИ́НТЕЗЛАУ** *ф.* 1) Синтез (*1 мәгъ.*) ысулы белән тикшерү; кушып-берләштереп гомумиләштерү. *Аерым фәннәр тарафыннан тәкъдим ителгән нәтиҗәләрне бер-берсе белән чагыштырып, гомумиләштереп, синтезлап, объектив нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин.* Мирас. *Татар әдәбияты Көнчыгыштан гына түгел, Көнбатыштан да килгән традицияләрне синтезлау юлы белән үсеш алган.* Казан утлары

2) Синтез (*3 мәгъ.*) ысулы белән барлыкка китерү, ясау, табу. *Үз җисемнәрен төзү өчен, яшел үсемлекләр углекислый газдан, судан һәм минераль тозлардан төрле-төрле органик матдәләр синтезлыйлар.* Е.Солодухин. *Сөт шикәре организмда аксымнар, майлар, витаминнар, ферментлар синтезлауда катнаша торган матдәләр составына керә.* Р.Абдуллина

**Синтезлап бару** Регуляр, эзлекле рәвештә синтезлау. *Автор романда документаль һәм әдәби башлангычларны шагыйрь иҗаты хакындагы бәяхөкемнәре һәм фәнни карашлары белән үреп, синтезлап бара.* Т.Гыйлаҗев

**Синтезлап тору** Даими рәвештә синтезлау

**Синтезлап чыгу** Барысын, бөтенесен дә синтезлау

**Синтезлый башлау** Синтезларга тотыну

**СИНТЕ́ТИК** *с.* 1) Синтез (*1 мәгъ.*) кулланууга нигезләнгән. *Тикшеренүнең синтетик ысулы*

2) *хим.* Синтез (*3 мәгъ.*) ысулы белән бәйле, шуңа нигезләнгән. *Синтетик ысул. Синтетик лаборатория*

3) *хим.* Синтезлап табылган; ясалма. *Синтетик нәрсәләр киеп, синтетик азыклар ашап, үзебез дә синтетикага әйләнеп китмик тагын.* Г.Хөсәенов. *Синтетик минераль пигментларны табу өчен, минераль чимал термик эшкәртелә.* Төзү материаллары

4) *лингв.* Сүз формалары белән белдерелгән (грамматик мәгънәләр тур.); ярдәмче сүзләрдән файдаланмыйча төзелгән. *Шарт мөнәсәбәте аналитик һәм синтетик чаралар белән берьюлы белдерелә.* Ф.Галләмов. *Синтетик гади җөмлә. Синтетик иярчен җөмлә*

5) Аерым өлешләрне берләштерә, кушып карый торган; гомумиләштерә торган. *1930 елларда татар әдәбият белемендә кызыклы эзләнүләр бара, һәм, нәтиҗә буларак, синтетик вариантта культура-тарих мәктәбе формалаша.* Ә.Закирҗанов. *Синтетик театр*

6) *сөйл.* Чын булмаган, ясалма. *Чын галим белән синтетик, «заманча» ясалма докторлар, кандидатлар арасындагы аерманы күрергә синдә өйрәндем.* М.Мәһдиев. *Советча яңа кеше образы, һомосоветикус тибы, кешелеклелек, миллилек, гаделлек төшенчәләреннән мәхрүм ителгән синтетик натуралар.* А.Хәлим

**СИНТЕ́ТИКА** *җый. и. рус* Химик синтез ысулы белән табылган материаллар һәм шулардан эшләнгән әйберләр. *Затлы товар – чын күннән сумкалар, перчаткалар ---. Синтетика дигән алдавычның заты да юк.* М.Мәһдиев. *Аннан поляк товарлары һәр ноктада өелеп ята, халык аларны бик үк өнәми, синтетика тирләтә, тәнне сулатмый дип, киндер тукымалардан тегелгән кием-салым сорый иде.* Н.Гыйматдинова

**СИ́НУС** *и. лат.* 1) *мат.* Туры почмаклы өчпочмакта каршы як катетның гипотенузага чагыштырмасына тигез булган тригонометрик функцияләрнең берсе. *Гаҗәпләнүемә каршы Рөстәм башын күтәреп карап елмайды да тагын синуслар, косинуслар арасына кереп чумды.* К.Кара

2) *анат.* Куышлык. *Киләләр, карыйлар, тыңлыйлар, «синус тахикардиясе» дип китеп тә баралар.* А.Гыйләҗев. *Эчәклек һәм сидек-җенес синусы тышка мөстәкыйль тишемнәр белән ачылмый, ә клоакага кушыла.* Биология

**СИНУСО́ИДА** *и. лат. мат.* Почмак үзгәрүенә бәйле рәвештә синусның үзгәрүен күрсәтә торган график

**СИНХРОН** *с.* **1.** 1) Бер үк вакытта була яки башкарыла торган. *Алдан барган ике пар ишкәкчеләрнең синхрон хәрәкәтләре – үзе бер шигъри күренеш.* Р.Фәйзуллин. *Синхрон тәрҗемә ясаучылар гадәттә икәү эшли: унбиш минуттан соң берсе икенчесен алыштыра.* Сөембикә

2) *лингв.* Синхрониягә (*2 мәгъ.*) караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Фәндә синхрон метод*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер үк вакытта, бердән. *Ниһаять, сәгать угы уникегә якынлашканда, уң як һәм сул як ишекләр синхрон ачылып, ике бүлмәдән ике ханым чыга.* Ә.Зарипов

2) *лингв.* Синхрония (*2 мәгъ.*) принципларына таянып, шуның нигезендә. *Шулай итеп, диалектларны синхрон тасвирлаган очракта, чираттагы бурычларның берсе булып диалект телен модельләштерү санала.* Фән һәм тел

**СИНХРОНИЗА́ТОР** *и. гр. техн.* Төрле аппарат, механизм, программа һ.б.ш.ларның төрле хәрәкәтләрен, гамәлләрен, функцияләрен вакыт ягыннан бергә туры китерү җайланмасы, синхронлаштыру җайланмасы. *Тирбәнешләр синхронизаторы. Автомобиль синхронизаторы. Электр машинасы синхронизаторы*

**СИНХРО́НИК** *с. лингв.* Синхрониягә (*2 мәгъ.*) караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Грамматика фәне телне һәм сөйләшне синхроник планда гына түгел, ягъни хәзер ничек булса, шул хәлендә генә өйрәнеп калмый, аны диахроник планда да өйрәнә.* Татар грамматикасы

**СИНХРОНИ́Я** *и. гр. кит.* 1) *к.* **синхронлык**

2) Тел күренешләренең бер чорга каравы

**СИНХРОНЛАШТЫРУ** *ф.* Нинди дә булса эшнең, процессның үтәлешен вакыт ягыннан башкасы белән туры китерү, тәңгәлләштерү. *Автоматик синхронлаштыру*

**Синхронлаштыра башлау** Синхронлаштырырга тотыну

**Синхронлаштыра төшү** Бераз гына синхронлаштыру

**Синхронлаштырып бетерү** Синхронлаштыруны тәмамлау

**СИНХРОНЛЫК** *и.* Ике яки аннан да артык җисем, кеше, механизм һ.б.ш.ның хәрәкәтләрендәге, эш-

гамәлләрендәге вакыт ягыннан бердәйлек, координацияләлек

**СИ́НЬКА** *и. рус* 1) Тукыма, кәгазь, юылган кер һ.б.ш. нәрсәне зәңгәрле торган буяу. *Ижауга барып, кара борыч, такта чәй, сабын-синька – тагын әллә ни-нәрсәләр алып кайтып сатарга тотынды.* Р.Батулла

2) Сызымнарның контактлы бастыру юлы белән зәңгәр төсле кәгазь өстенә төшерелгән күчермәсе

**СИ́НЬКАЛАУ** *ф. сөйл.* Синька белән буяу. *Урын-җир җәймәсен синькалау. Тәрәзә челтәрләрен синькалау*

**Синькалап алу** Тиз арада синькалау

**Синькалап бетерү** Барысын да синькалау; синькалау эшен тәмамлау

**Синькалап кую** Алдан ук синькалау

**Синькалап тору** Гел, даими рәвештә синькалау; сөйләү моментында синькалау

**Синькалый башлау** Синькаларга тотыну

**Синькалый төшү** Бераз синькалау

**СИ́НЬКАЛЫ** *с.* Синька кушылган, синька салынган. *Күк йөзе шундый зәңгәр: аны яңа гына синькалы су белән юып төшкәннәр төсле.* Г.Гобәй

**СИНЬОР** *и. лат.* 1) Урта гасырларда Италиянең шәһәр-дәүләтләрендә бердәнбер идарә итүче, хаким

2) Италиядә ир-атка мөрәҗәгать итү һәм атау сүзе. *Ләкин безнең гид – өлкән яшьтәге кеше синьор Фернандо – утрауның «кырыс тарихы» турында берни дә әйтми.* М.Мәһдиев

**СИНЬО́РА** *и. ит.* Италиядә хатын-кызга мөрәҗәгать итү яки аны атау сүзе; ханым

**СИНЬОРИ́НА** *и. ит.* Италиядә кияүгә чыкмаган кызларга мөрәҗәгать итү сүзе; туташ

**СИНЭКОЛО́ГИЯ** *и. гр. махс.* Экологиянең хайваннар, үсемлекләр һәм микроорганизмнарның бергә тереклек итүен – биоценозларны өйрәнә торган бүлеге

**СИОНИЗМ** *и. яһүд сәяси* XIX йөз ахырында Европа илләрендә барлыкка килгән һәм еврейларның милли үзаңын үстерү, Фәләстыйн җирендә үз дәүләтләрен төзү максатын куйган иҗтимагый агым һәм шуның идеологиясе. *Татарлар һәр шовинистик адымга һәм, гомумән, сионизмга, агрессиягә каршы.* Ватаным Татарстан

**СИОНИСТ** *и. рус* Сионизм тарафдары

**СИОНИ́СТИК** *с.* Сионизмга нигезләнгән, шундый рухтагы, шуңа мөнәсәбәтле. *Кызганыч ки, бүгенге көндә Америка хакимияте халыкара мәсьәләләрдә, бигрәк тә милли сәясәттә, сионистик даирәләр тәэсиренә ияреп, Гыйрак авантюрасына бирелә.* Р.Вәлиев

**СИП-** Кайбер сыйфатлар белән килеп, аларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә (мәс., *сип-симез, сип-сирәк*)

**СИПАҺИ** *и. фар. тар.* 1) Гаскәри, солдат. *Борынгы замандагы (яллланган) атлы гаскәри – сипаһи сүзе бездә күптән кулланылмый.* Р.Әхмәтьянов

2) Госманлы дәүләтендә солтан гвардиясендәге атлы гаскәри

3) Һиндстанда төрле чорларда җирле халыктан хәрби хезмәткә ялланган солдат

**СИПКЕЛ** *и.* Бит яки тәннең кайбер урыннарында булган, аеруча язын һәм җәен нык беленә торган саргылт яки коңгырт тимгелләр яисә шуларның берсе. *Аңарга Хафиз: «Мин сине әнә шул бит очындагы ике сипкелең өчен яратам», – дигән иде.* Ф.Хөсни. *Әгәр дә ул кызның --- ике бит алмасында вак кына сипкеле җемелдәп тормаса, егетнең йокылары качмас та иде.* М.Кәрим

**СИПКЕЛЛӘНҮ** *ф.* Сипкелләр барлыкка килү, сипкел чыгу

**Сипкелләнә бару** Вакыт узган саен ныграк сипкелләнү

**Сипкелләнә төшү** Бераз сипкелләнү; тагын да сипкелләнү

**Сипкелләнеп бетү** Бик сипкеллегә әйләнү

**СИПКЕЛЛӘ́Ү** *ф. к.* **сипкелләнү**. *Борын сипкелләү*

**Сипкелләп бетү** Бик сипкеллегә әйләнү

**Сипкелли бару** Вакыт узган саен ныграк сипкелләү

**Сипкелли төшү** Бераз сипкелләр барлыкка килү

**СИПКЕЛЛЕ** *с.* Сипкеле булган, сипкелләр төшкән. *Аңа охшаган бердәнбер малай зәңгәр күзле, дәү борынлы, сипкелле Ахун гына булып чыкты.* Г.Бәширов. – *Кичә --- стадионга чыгып карасам, ни күрим, җыен малай-шалай арасында Фуат чабып йөри, – дип хәбәр итте Зәйтүнә – вак сипкелле һәм чәрелдек тавышлы кыз.* Э.Касыймов

**СИПКЕЧ** *и.* 1) Сыеклыкны бөркеп сибә торган махсус җайланма яки шундый җайланмасы булган савыт. *Яшелчәгә сипкеч белән су сибү*

2) *сөйл. к.* **сиптергеч**. *Агу сипкеч. Ашлама сипкеч. Көл сипкеч*

**СИПЛӘТҮ** *ф. йөкл. к.* **сипләү**. *Үткән көз өйне дә сипләтеп, алты почмаклы иттем.* Г.Ибраһимов. *Кемдер мич чыгаручы белән мич чыгартырга килешә; кайсы каралты-курасын сипләткән була.* В.Нуруллин

**Сипләтеп җибәрү** Тиз арада сипләтү

**Сипләтеп чыгу** Берсен дә калдырмыйча сипләтү

**СИПЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бураның яки башка корылманың тузган, черегән ниргәсен алыштырып яңарту, ремонтлау. *Корылмаларны төзәтү, сипләү, реставрацияләү һәм ныгыту нәтиҗәле материаллар куллану һ.б. төрле юллар белән башкарыла.* Төзү материаллары. *Өй алай яңадан түгел, әмма черегән бүрәнәләрне бик пөхтәләп сипләгәннәр.* Казан утлары

2) Баш сабып һ.б.ш. рәвештә аяк киемен яңарту. *Аларның улларын мин мәктәбемә үз ризалыклары белән алдым. Аягына юк иде, үземнең иске читегемне сипләп бирдем.* Ә.Фәйзи

3) Гомумән, искергән, таушалган нәрсәләрне элекке хәленә китерү, төзәтү, ямау. *Иске бишмәтне әйләндереп сипләү*

4) *күч.* Рәткә, тәртипкә китерү. *Искене иплəп ки, тузганны сипләп ки.* Әйтем

**Сипләп алу** Кыска вакыт эчендә сипләү. *[Хөббениса:] Аннары әйтә, хәзерләнебрәк торыгыз, уракка төшкәнче, сезнең өйне сипләп алырга карар иттек, ди.* Р.Төхфәтуллин

**Сипләп бетерү** Барсын да сипләү; тулысынча сипләнгән хәлгә китерү

**Сипләп җибәрү** Тиз арада сипләү; сипләргә керешү. *Яңа оек бәйләтеп*

*бирделәр. Әни бүрекне сипләп җибәрде.* М.Гафури

**Сипләп кую** Берәр эш-хәлгә кадәр, алдан ук сипләү. *Иртән торуыбызга коебызның бурасын сипләп куйганнар.* Г.Галиев

**Сипләп тору** Даими рәвештә сипләү

**Сипли төшү** Бераз сипләү

**СИПМӘ** *с. диал.* Сибәләп яуган. *Сипмә яңгыр*

**СИПТЕРГЕЧ** *и.* Сыеклыкларны, шулай ук вак бөртекле нәрсәләрне бөркеп сиптерә торган махсус җайланма яки машина. *Бер гектар игенне эшкәртү өчен, 0,75–1,5 килограмм препарат алына, һәм ул гади сиптергечләр белән сиптергәндә – 150–200 литр, ә самолёт ярдәме белән сиптергәндә, 50 литр суда эретелә.* Г.Галиев. *Чабыш артыннан юлга су сиптергеч машина чыкты.* К.Тимбикова. *Безгә әнә буяу сиптергеч машина кирәк.* Г.Ахунов

**СИПТЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сиптерү**. *Белми көн дә күзәтә үзләрен. Энекәше Үсәрдән вакытында су сиптертә, төпләрен йомшарттыра.* Ф.Зыятдинов

2) *к.* **сиптерү**. *Акча түләп яллаганмыни: түшен киереп баскан да Бикташтан бакчаларына безнең мичкәдән шабыр-шобыр су сиптертә!* М.Маликова

**Сиптертә башлау** Сиптертергә тотыну

**Сиптертә тору** Даими яки регуляр рәвештә сиптертү

**Сиптертә төшү** Бераз сиптертү; тагын да күбрәк сиптертү

**Сиптертеп алу** Тиз арада сиптертү

**Сиптертеп бару** Рәттән сиптертү

**Сиптертеп җибәрү** Кинәт, искәрмәстән сиптертә башлау

**Сиптертеп тору** Һаман, гел сиптертү

**СИПТЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* 1) Башка берәүне яллап, боерып, үтенеп, сибү эшен башкарту. *Балалардан түтәлләргә су сиптерү*

2) Нинди дә булса сыекчаны яки газны берәр төрле җайланма, сиптергеч белән бөркү, пошкырту, сибү. *Гөлҗиһанның басу юлына су сиптергәннәрен күргәне юк иде, хәйран калды.* К.Тимбикова. *Теге өйгә барып керүгә, йөзенә ниндидер газ сиптергәннәр.* И.Хуҗин

3) *күч.* Бер яки берничә коралдан бертуктаусыз, еш, озак, көчле ату. *– Аңлыйсызмы, – дим мин, – бу безнең артиллерия бит! Ишетәсезме, ничек сиптерәләр!* А.Расих. *Самолётлар, астан гына очып, гранаталар ташлый, пулемёттан сиптерә.* Х.Камалов

4) *күч. сөйл.* Бик яхшы, оста сөйләү, җырлау, уен коралларында уйнау һ.б.ш. *Гыйльми түти утырган жиреннән кулын чәбәкләргә кереште: – Әйттер шуны, сиптер шуны!.. Инде лә, инде лә!* Г.Бәширов. *Ә бүген ул, кызган башын кыйгайтып алган да, сигез телле тальянкада сиптерә.* М.Мәһдиев

**Сиптерә башлау** Сиптерергә тотыну. *Нәкъ шул вакытта кызыл гаскәр ягындагы батареялардан берсе үзенең снарядларын кызыл гаскәр өстенә сиптерә башлады.* Ш.Усманов. *Мин бер түмгәк артына җайлап яттым да автоматымнан немецлар өстенә пуля сиптерә башладым.* Ф.Яруллин

**Сиптерә тору** Әлегә сиптерү; әледән-әле сиптерү. *Кичә таралганнан соң, теплоходка кайтканда да, шаян штурман һаман Нәзифә тирәсендә булды, бетмәс-төкәнмәс мәзәкләрен, күңелле шаяртуларын туктаусыз сиптерә торды.* С.Сабиров

**Сиптерә төшү** Бераз сиптерү; тагын да күбрәк сиптерү

**Сиптереп алу** Бераз гына, тиз генә сиптерү. *Шалин шунда граната ыргытты, мин сугышчылар белән өске якка чыктым, блиндаж ишегенә автоматтан бер сиптереп алдым.* Х.Камалов

**Сиптереп бетерү** Бөтенесенә дә сиптерү; булган нәрсәнең барысын да сиптерү

**Сиптереп җибәрү** Көтмәгәндә сиптерү, кинәттән сиптерү

**Сиптереп тору** Даими рәвештә сиптерү; хәзерге моментта сиптерү. *Көпшәләр су сиптереп тора, чипчиста урамнар, хәрәкәт аз, шәһәрнең тоныклык гүләве монда ишетелми.* Р.Батулла. *Җир куеныннан да эрелеваклы чишмәләр атылып чыга: кайсылары чишмә килеш кала, кайсылары елгага әверелә, кайсылары көчле фонтан булып, вулкан атылгандай сиптереп тора иде.* М.Кәбиров

**Сиптереп узу** Узып барышлый сиптерү; чират, тәртип буенча сиптерү. *Истребительләр тагы түбәннән генә ут сиптереп уздылар.* Х.Камалов

**СИРАЯТЬ** *и. гар. иск.* Бер нәрсәдән икенчесенә күчү, таралу

**СИРА́ЯТЬ ИТҮ** *ф. иск.* Йогынты ясау, тәэсир итү; йогу, күчү, таралу. *Көз дигән бер мәраз җанга сираять итә.* Г.Ибраһимов. *[Мөштәри:] Безнең карт хәзрәт кичә җомгада вәгазь сөйләде: «Шул сул җәдитләргә һич аралашмагыз, --- аларның явызлыгы йогадыр, сираять итәдер ---».* Ш.Мөхәммәдев

**СИРА́ЯТЬ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **сираять итү**. *Бармагыңны кистермәсәң, авыру бөтен бәдәнеңә сираять кылыр.* К.Насыйри

**СИРӘГӘЙТЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **сирәгәйтү**. *Аның нигезендә предприятиеләрдә махсус тикшерү сирәгәйтелә.* Кызыл таң

**СИРӘГӘЙТҮ** *ф. к.* **сирәкләү**. *Ә шулай да янә атна-ун көн нервыларын туздырып, аларның сафларын сирәгәйтеп, үзебезнекен ишәйтеп, контрһөҗүмгә зур әзерлек белән күчкәндә, куәтле дулкын тагы да көчле каршылыкка очрамаска мөмкин.* С.Поварисов. *Ул, гадәтенчә, вакыт-вакыт кергәләп хәл белешкәли иде, анысын да хәзер сирәгәйтте.* Ф.Яхин

**Сирәгәйтә бару** *к.* **сирәкли бару**. *Алган яралар һәм авырулар ел саен аларның сафларын сирәгәйтә бара.* Шәһри Казан

**Сирәгәйтә башлау** *к.* **сирәкли башлау**

**Сирәгәйтә төшү** *к.* **сирәкли төшү** *Сания апаларда булса да, кичләрен чыкмый, хәтта анда кайтуны да сирәгәйтә төште.* Безнең гәҗит

**Сирәгәйтеп алу** *к.* **сирәкләп алу**

**Сирәгәйтеп бетерү** *к.* **сирәкләп бетерү**. *Ә шул вакытта көз-кыш көннәрендә авыл урамнарында дөм караңгы: баганалардагы утларны өзеп, лампочкаларны сирәгәйтеп бетерделәр – экономиялиләр.* Татарстан яшьләре

**Сирәгәйтеп тору** *к.* **сирәкләп тору**

**Сирәгәйтеп чыгу** *к.* **сирәкләп чыгу**

**СИРӘГӘЮ** *ф.* 1) Сирәк (*1 мәгъ.*) булып калу, сирәкләнү, ешлыгы, куелыгы

кимү. *Урманнар нык киселеп, шактый сирәгәйгәннәр. Чәч сирәгәю*

2) Тыгызлыгы, куелыгы кимү, сыегаю (һава, томан һ.б.ш. тур.). *Тауларга күтәрелгән саен, һава сирәгәя*

3) Сан, күләм ягыннан азаю, кими бару. *Солдатлар арасында шау-шу басылды, тегеләр хакында сөйләү сирәгәйде.* М.Гафури. *1943 елның язы иде. Авылда ир-ат бөтенләй сирәгәйде.* М.Кәрим. *Гаскәр йончыды, сафлар сирәгәйде, корал, сугыш кирәк-яраклары җитешмәде.* Г.Гобәй

4) Көче, киеренкелеге һ.б. ягыннан кимү. *Керпе, кышын оясына яшеренеп, тирән йокыга тала. Аның тән температурасы төшә, сулышы сирәгәя.* Биология

**Сирәгәеп бару** Эзлекле рәвештә сирәгәю. *Ә безнең авылда хәзер этләр дә сирәгәеп бара. Бала-чага кемне иркәләп, кем турында кайгыртып яшәсен?* Ф.Яруллин. *Татарстанда бер төре – гади артыш --- үсә. Сирәгәеп бара торган үсемлекләргә керә.* Агулы үсемлекләр

**Сирәгәеп бетү** Тәмам сирәгәю, нык сирәгәю. *Утызынчы еллар азагында Сталин золымыннан исемнәре тапланып, сирәгәеп беткән язучылар арасыннан яңа «баганалар» күтәрү кирәк була.* М.Галиев

**Сирәгәеп калу** Берәр сәбәптән соң сирәгәю. *Тигез, кыска гына итеп кыркылган электәге карасу чәчләре инде көмешләнеп аралашкан, баш түбәсендәгеләре сирәгәеп тә калган иде.* Н.Хәсәнов. *Бу урында биек наратлар сирәгәеп кала, аннары бөтенләй күренми башлыйлар.* К.Тимбикова

**Сирәгәеп китү** Соңгы вакытта сирәгәю. *Нишләптер соңга таба Илдарның хатлары сирәгәеп китте.* А.Әхмәтгалиева

**Сирәгәя бару** Акрынлап, торган саен сирәгәю. *Бәйрәмнәр сирәгәя бара иде.* Ш.Усманов. *Авылның эчми, тартмый, сүгенми торган картларыннан бөтен бер буын инде сирәгәеп бара иде.* М.Мәһдиев

**Сирәгәя башлау** Сирәгәюгә таба бару. *Дәүләтгәрәй абзыйлар Ленин урамының иң кырыенда йорт урыны алып, шунда таудай яңа өй салып чыккач, аралар ерагайгач, ике арадагы мөнәсәбәтләр дә суына төшкәндәй булды, һәм барып-килеп йөрүләр сирәгәя башлады.* Н.Фәттах. *Урамда инде халык сирәгәя башлады. Вакыт бик соң, күрәсең.* Л.Ихсанова

**Сирәгәя төшү** Тагы да сирәгәю; беркадәр сирәгәю. *Әмма авылның үзендә халык сирәгәя төшкән булып чыкты: колхоз эшләре механикалаштырылгач, авылда фәкать комбайн-трактор, ферма-фәлән тирәсендә эшләүчеләр генә торып калды, күпчелек исә, бигрәк тә яшьләр, шәһәр җиренә китү ягын карады.* К.Миңлебаев. *Туксанынчы елларда мәйданда кемнәр булса, хәзер дә шул берничә бөртек кеше икән, дөрес, рәтләре сирәгәя төшкән.* Ф.Бәйрәмова

**СИРӘК** *с.* **1.** 1) Үзара тыгыз урнашмаган, еш булмаган, куе түгел. *Валентин Иванович Равилне күреп, гаҗәпсенеп, сирәк сары кашларын сикертеп куйды.* В.Нуруллин. *Кыз уймак борыны читләрендәге сирәк сипкелләре өстенә юка гына итеп кершән якты.* Казан утлары

2) Бер-берсеннән ераграк урнашкан, еш булмаган. *Аның күз алдыннан сирәк бакчалар, аерым йортлар, чәйханәләр үтә.* Ш.Усманов. *Өч-дүрт йортлы бер рус авылын үткәч, басу уртасындагы сирәк кенә каенлыкка тукталдык.* М.Кәрим. *Урман алдында, качаклар юлы өстендә, сирәк куаклы аланлыклар.* Т.Галиуллин

3) Тыгыз тукылмаган, тыгызлыгы җитмәгән. *Сирәк иләк көн дә кирәк, нечкә иләк бәйрәмдә кирәк.* Мәкаль. *Сирәк тукыма. Сирәк киндер*

4) Куе булмаган, сыек, тыгыз түгел (һава, томан тур.). *Сирәк кенә зәңгәр томан аша күренеп калган кояш шикелле, Мин очратам сине...* М.Җәлил

5) Еш очрамый торган, киң таралмаган, аз. *Соңгы елларда без илаһилыкны, сирәк кешеләргә эләгә торган талант төшенчәсен онытып барабыз түгелме?* Г.Ахунов. *Рәхмәй бик күп галимнәрнең дә төшләренә генә керә торган сирәк басмаларны гына җыя.* Ф.Яруллин

6) Озак вакыттан соң була торган, еш булмый торган. *Сирәк күренеш*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сирәк (*1 мәгъ.*) булып яки сирәк итеп. *Тары Хәлимгә бу юлы, ничектер сирәгрәк күренде, һәм ул өенә кереп тормады, --- туп-туры районга, агроном янына китеп барды.* Г.Гобәй. *Бу якларда сирәк күренгәнчә, өйнең бакча ягында буйдан-буйга шактый иркен веранда да эшләнгән.* Казан утлары

2) Еш түгел, әллә нидә бер. *Кунакның сирәк килгәне кадерле.* Әйтем. *Хафизлар бүлмәсендә мондый уеннар сирәк уйналалар иде.* К.Тинчурин. *Бу ике гаилә сирәк йөрешәләр иде.* С. Рафиков. *Ул хәзергә кадәр дөньяда сирәк табылган әсәрләрне үзенә җыю белән мәшһүр.* Г.Гобәй

3) Әллә нидә бер, ара-тирә, аз. *Сирәк-сирәк кенә колоннаның яныннан, кар тузаны күтәреп, атлы ординарецлар чабып үтә.* Ш.Усманов. *Урамда әле кеше бик сирәк очрый.* М.Кәрим. *Озын, төз гәүдәле, горур борынлы, --- чыгынкы маңгайлы, зур үткен күзле кешеләр Арча кавемнәре арасында сирәк очрый.* Т.Галиуллин

4) Бер-берләренә ерак торып, ерак ара калдырып. *Казах далаларында авыллар сирәк урнашкан*

**3.** *хәб. функ.* Аз, җитәрлек түгел, уйлаганга караганда ким. *Мөхтәсимгә йомыш бирмәс кеше авылда сирәк иде.* М.Кәрим. *Сагынмый үткән сәгатем Сирәк бит, сирәк, сирәк...* Х.Туфан

◊ **Сирәк иләк биш юкә** Такылдык, сер тотмас кеше турында. *Әнә Сәрия, сирәк иләк биш юкә, монда сөйләшкәнебезне 14 нче бүлмәдәгеләргә кереп сайраган.* Н.Исәнбәт

**СИРӘКЛӘГЕЧ** *и.* Сирәкләү җайланмасы (коралы). *Кукуруз игүдә сирәкләгеч куллану*

**СИРӘКЛӘНДЕРҮ** *ф. к.* **сирәкләү** (*1 мәгъ.*). *Ә җитештерү эшләре, ягъни такта яру, бура бурау, төрле көнкүреш кирәк-яраклары ясау бары тик делянкаларны сирәкләндерү максаты белән генә алып барылды.* Ватаным Татарстан. *Тамыразык культураларын сирәкләндерү*

**СИРӘКЛӘНҮ** *ф. к.* **сирәгәю**. *Ул абзый да киткәч, миңа өйдән азык-фәлән килү тагы да сирәкләнде.* М.Гафури.

*Озын юлда дуслар сирәкләнә, җиде ятны дус-иш итәсе бар.* Н.Әхмәдиев

**Сирәкләнә бару** Торган саен сирәкләнү. *Әйе, ветераннарның, аларның тол җәмәгатьләренең дә сафы елдан-ел сирәкләнә бара.* Т.Нәҗмиев

**Сирәкләнә башлау** Сирәкләнү ягына үзгәрү; сирәкләнергә тотыну. *Сирәкләнә башлаган, анда-санда ак йөгергән шома чәч.* М.Мәһдиев. *Шулай күпмедер йөгергәч, ул урманның сирәкләнә башлавын, җир өстенең түбәнәюен шәйләде.* Н.Фәттах

**Сирәкләнә төшү** Бераз сирәкләнү; тагы да сирәкләнү. *Сирәкләнә төшкән рәшәткәләр, аларын да тап-тап булып тутык каплаган.* Р.Низамиев

**Сирәкләнеп бару** Эзлекле рәвештә сирәкләнү. *Дөресен әйтик: чын мәгънәсендә туган телнең нечкәлекләрен белгәннәр дә сирәкләнеп бара.* Р.Фәйзуллин. *Ләкин сирәкләнеп барды да ул хәлләр, тора-бара бөтенләй бетте.* Ф.Баттал

**Сирәкләнеп бетү** Бөтенләй сирәкләнү. *Кайчандыр ат кылыдай каты, куе сакал-мыегы сирәкләнеп беткән, һәм хәзер аның борын астында, ияк очында элекке гайрәтле чакларыннан калган ике-өч бөртек аксыл төкләр генә тырпаеп тора иде.* Н.Фәттах

**Сирәкләнеп калу** Берәр тәэсирдән соң сирәкләнгән хәлгә килү. *Өй түрендәге биек карт усак, сирәкләнеп калган зәгъфран яфраклары белән лепелдәп, нәрсәдер сөйли иде.* Р.Төхфәтуллин. *Җәзачылар төн җиткәнен генә көттеләр дә, чөй шикелле тыгыз сафка тезелеп, сирәкләнеп калган фетнәчеләр чылбырына ташландылар.* В.Имамов

**СИРӘКЛӘП** *рәв.* Сирәк кенә, сирәк-мирәк, әллә нигә бер. *Карт һәрбер сүзендә җитди вә чыдам күренә. Тик әби генә, сирәкләп, күзендәге яшен сөртеп куя.* М.Гафури. *Ара ерак булса да, Алатауга сирәкләп хәбәр килгәләде.* Г.Ибраһимов. *Сирәкләп кунакка бардылар, әмма ваклашып яшәмәде алар.* М.Кәрим

**СИРӘКЛӘТКЕЧ** *и. к.* **сирәкләгеч**

**СИРӘКЛӘТҮ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **сирәкләү 1.** (*1 мәгъ.*)

2) Сирәк (*1, 2, 5 мәгъ.*) итү, сирәгәйтү. *Вахит менә шундый авырлыкларны берничә рәт татыганнан соң гына, ул «хасиятле догалар»ны укуын сирәкләтте.* М.Гафури

**Сирәкләтә бару** Рәттән сирәкләтү, эзлекле рәвештә сирәкләтү

**Сирәкләтә төшү** Бераз сирәкләтү; тагын да сирәкләтү

**Сирәкләтеп бетерү** Бөтенләй, ахырына кадәр, нык сирәкләтү. *Бай, һәрвакыт чәйни-чәйни йолкып сирәкләтеп бетергән сакалын --- авызга бер-ике кабып чәйнәгәч, ары-бире йөри башлады.* Ш.Мөхәммәдев

**Сирәкләтеп килү** Электән үк, эзлекле рәвештә сирәкләтү

**Сирәкләтеп тору** Даими рәвештә сирәкләтү; хәзерге моментта сирәкләтү

**Сирәкләтеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр сирәкләтү

**СИРӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Сирәк (*1 мәгъ.*) итеп калдыру, сирәгәйтү. *Ә инде кукуруз тишелеп чыгып күзгә күренгәч тә, пунктирлап чәчелгән орлыкларның шытымын челтәрле тырма-кыргычлар белән сирәкләделәр.* М.Хәсәнов. *Сукаланган болынга чөгендер чәчтеләр дә, хәзер Камил һәр җәйне шунда бил бөгә, кара җирдә казына, әллә нәрсәсенә котырып үскән чөгендерне бер сирәкли, ике сирәкли.* Ф.Бәйрәмова

2) Сирәгәю, еш булмау. *Хатлар сирәкләде*

3) Кайдадыр йөрүне киметү, азайту. *Моңарчы минем янга еш керә идең, хәзер сирәкләдең.* Ә.Баян. *[Солтангалиев:] – Әйдүк, рәхим итегез, Зәки әфәнде! Соңгы араларда, нишләптер, сирәкләдегез. – Сирәкләү генә түгел, табанны ялтыратыр вакыт җитте, – диде Зәки Вәлиди.* Р.Мөхәммәдиев

**Сирәкли бару** Эзлекле яки регуляр рәвештә сирәкләү

**Сирәкли башлау** Сирәкләргә тотыну. *Аучы, улы белән килененең хәлен белергә баштарак еш килеп йөрсә дә, кышын сирәкли башлады.* З.Мурсиев

**Сирәкли төшү** Бераз сирәкләү; тагын да сирәкләү. *Кишерне сирәкли төшү*

**Сирәкләп алу** Бераз, җиңелчә яки тиз генә сирәкләү. *Чөгендер белән кишерне тиз генә сирәкләп алу*

**Сирәкләп бетерү** Барысын да сирәкләү; нык сирәкләү. *Әбием әйләнеп килгәндә, бер түтәлне сирәкләп бетергән идем инде.* Ф.Зыятдинов

**Сирәкләп тору** Даими яки регуляр рәвештә сирәкләү; хәзерге моментта сирәкләү. *Шулай ук төп үсентенең вак сабакларын сирәкләп торсаң, чәчәкләре мул, эре була.* Кәеф ничек?

**Сирәкләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр сирәкләү

**СИРӘКЛЕК** *и.* 1) Сирәк булу. *Яшь, мыегы да кара, сирәклеген сизмисең, килешеп тора.* Ф.Яхин. *Күзләр матур булгач, теш сирәклеге чүп кенә, авызны йомыбрак йөрергә туры килер, дип фикер йөртә кыз.* Д.Каюмова

2) Берәр нәрсә сирәк урнашкан, үскән урын. *Азрак баргач, печән сирәгәйде, сукмак та шушы сирәклектә югалды.* Г.Нургатина

**СИРӘ́К-МИРӘК** *с.* **1.** Бик сирәк була, сирәк очрый торган. *Сирәк-мирәк таш төялгән авыр вагоннар, тростан ычкынып китеп, артка тәгәриләр.* А.Гыйләҗев. *Әнисеннән килгән сирәк-мирәк бүләкләр, шалтыратулар да Галиянең күңелендәге караңгы почмакка яктылык өстәп тора иделәр.* А.Нургатина

**2.** *рәв. мәгъ.* Әллә нидә бер, шактый вакыт арасы белән. *Борын безнең авылга урыс арасыннан, сирәк-мирәк кенә, сөтне күп бирә торган яхшы нәселле сыер килеп эләккәли иде.* Ә.Еники. *Ә Сибгат абый белән сирәк-мирәк күрешкәләргә туры килде.* Ф.Яруллин

**СИРӘ́К-САЯК** *рәв. к.* **сирәк-мирәк**. *Бу аякларның кышын киез итек, язын-көзен күн итек күргәне юк. Сирәк-саяк чабата тисә тия шунда.* М.Кәрим. *Гаять биек үлән, сирәк-саяк чавыллар күренә, алар я бик биек, я булмаса үзе бер кечкенә болыт кисәге кадәр җәенке ябалдашлы.* З.Мурсиев

**СИРӘ́К-СИРӘК** *рәв. к.* **сирәк-мирәк**. *Дөрес, аннан соң да сирәк-сирәк хатлар языштык.* М.Җәлил. *Тик ул сирәк-сирәк иреннәрен генә чәйнәп ала.* Ш.Усманов. *Сирәк-сирәк мылтык һәм туп аткан авазлар килә.* Р.Гали

**СИРЕ́НА** *и. гр.* 1) Грек мифологиясендә: матур җырлавы белән диңгезчеләрне һәлакәтле урыннарга алдап кертә

торган хатын-кыз башлы, кош гәүдәле диңгез заты

2) *зоол. күпл.* Суда тереклек иткән имезүчеләр классыннан күбрәк яр буендагы сай суларда яши торган, үлән ашаучы зур хайваннар отряды

3) Төрле югарылыктагы көчле тавышлар хасил итү өчен кулланыла торган тавыш генераторы, тавыш сигналы бирү җайланмасы. *Яр буендагы постларда, маякларда сиреналар җылый.* М.Мәһдиев. *Әгәр ара-тирә сирена үкертеп алсаң, --- милициянең район бүлегенә кадәр араны «Жигули» ике минутта үтә ала.* К.Кәримов

4) Шундый җайланма ярдәмендә бирелгән кискен һәм улауга охшашрак сузынкы гудок сигналы. *Валерий Быковский очканда, мәйдандагылар окопларга барып урнашкач, сирена яңгырый.* Кызыл таң

**СИРЕНЬ** *и. лат. бот.* Зәйтүнчәләр семьялыгыннан шома куе яшел яфраклы, сыек шәмәхә яки ак төстәге чәчкәләре күпереп торган чукларга тупланган, хуш исле декоратив куак. *Сирень чәчәгенең исләре хәтерләтә язгы кичләрне.* Җыр. *Сирень чәчәкләре безнең тормышыбызны бергә бәйләде.* И.Гази

**СИРО́ККО** *и. ит. геогр.* Урта диңгез бассейнында көньяктан, көньяккөнбатыштан исә торган эссе, коры тузанлы көчле җил. *[Сирокко] яз көне 2–3 көн тоташ исә, температураны 35°С ка күтәрә.* Физик география

**СИРОП** *и. фр.* 1) Суда эретелгән шикәр, шикәр суы, ширбәт. *Балны фальсификацияләү сиропка төрле стабильләштерү, буягыч һәм хуш ис бирә торган өстәмәләр кушу юлы белән арзан имитация җитештерүче кайбер компанияләрнең бизнес концепциясенә әйләнде.* Татарстан

2) Җиләк-җимеш суына шикәр кушып әзерләнгән татлы эчемлек. *Шулар янында фрауның токымлы мүкләге биргән сөт һәм өйдә ясалган татлы чөгендер сиробы да бар.* А.Тимергалин. *Суытылган мусс креманкаларга бушатыла һәм табынга җиләк-җимеш сиробы белән бирелә.* Көнкүреш хезмәте

3) Даруларның шундый сыеклык рәвешендәге формасы. *Юкка гына даруларның формасы капсула, борчак, сироп формасында ясалмаган. Димәк, кеше организмына ул шулай файдалырак.* Н.Кубрина

**СИРОПЛА́У** *ф.* Сироп кушу, сироп катнаштыру

**Сироплап бетерү** Сироплау эшен тәмамлау

**Сироплап кую** Алдан ук сиропланган хәлгә китерү

**Сироплый башлау** Сиропларга тотыну

**Сироплый төшү** Бераз сироп кушу

**СИРОПЛЫ** *с.* Сироп кушылган, сироп катнаштырылган, сироп салынган. *Сироплы компот*

**СИРПЕЛЕШ** *и.* Берәр хис, халәтнең чагылышы, тышкы билгеләре. *Әмма ул шатлык, яшергән саен, якты нур булып, Нуриасманың күзләренә иңде, дәртле сирпелеш булып, күз-керфекләренә эленде.* Ф.Садриев

**СИРПҮ** *ф.* 1) Җиңелчә селкү, җилпү, кагу (канат, керфек һ.б.ш.ларны). *Ул, керфекләрен еш-еш сирпеп, азрак көлемсерәп килә.* Г.Бәширов. *Чыкса, авыл өстеннән, җай гына канат сирпеп, торналар китеп бара иде.* М.Мәһдиев

2) Күзнең кырые белән генә яки тиз генә карап алу; караш ташлау. *[Кызлар] керфек асларыннан гына аңа күз дә сирпеп куйгалыйлар.* Ф.Хөсни

3) Сыек яки вак нәрсәләрне кискен хәрәкәт ясап селтәп түгү, сибү. *Су сирпү*

4) Сыек нәрсәне пошкырту, бөркү. *Саллы Ык исә, корт анасы кебек, бөтен чишмә-инешләрне үз канат астына җыеп, бормаланып кире кайта-кайта, кымыз үләне кайнап үскән үзәннәргә шифалы дым сирпеп, олы сулар тарафына вәкарь белән генә кузгала.* М.Галиев

5) Капыл селтәп берәр якка җибәрү, юнәлеш бирү, урыныннан кузгату. *Ул, Давытның карашын тоеп, бөдрәләрен сирпеп, башын борды һәм боздай салкын карашы белән аңа чыгып китәргә боергандай итте.* М.Маликова. *--- Гөлчирә сыгылмалы гәүдәсен оста гына читкә тайпылдырды һәм, куе коңгырт чәчләрен сирпеп җибәреп, күңелле итеп көлде.* Д.Бүләков

6) Бөркү, мул итеп сибү, тарату (яктылык, нур һ.б.ш.лар тур.). *Дамирның сөю сирпеп торган күзләре, һәрвакыт якларга әзер омтылышы, мәхәббәтне олылый белүе – болар һәммәсе Җәүһәр өчен кадерле, бик тансык иде.* Ф.Яруллин. *Әйе, мәхәббәт – олы илаһи кичереш, ул кешенең яшәешенә нур сирпи, мәгънә бөрки.* Т.Галиуллин

7) Аңкыту, чыгару, тарату (ис тур.). *Чәчәкләр Хәятка карап көләләр һәм әллә кай җирләреннән генә аның борынына берничә исне берьюлы сирпеп торалар иде.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Тавыш, караш, фикер, мөгамәлә һ.б.ш.лар белән хисне, халәтне чагылдыру, сиздерү, белдерү. *Алар, ерак урманнар хакында уйланып, чак кына ямансу балкышлар сирпеп, күңелне каядыр дәшә, җилкендерәләр.* Ә.Баян. *[Кызның] шуклык, наянлык сирпегән күзләре аңа текәлде.* Ш.Хөсәенов

**Сирпеп алу** Тиз генә, бер тапкыр сирпү. *Их, карап торулары, күз сирпеп алулары…* Җыр. *Кыз миңа күзен генә сирпеп алды да бер сүз дә әйтмәстән чигә бирде.* Г.Бәширов. *Тукай, шөбһәләнеп, аның йөзенә күз сирпеп ала.* И.Нуруллин

**Сирпеп җибәрү** Кисәк яки бераз гына сирпү. *Күкрәгенә таралып төшкән чәч толымын кулы белән артка сирпеп җибәрде дә, бөгелә-сыгыла, атлар торган кибән ягына йөгерде.* Д.Бүләков

**Сирпеп йөрү** Озак кына яки һәр җирдә сирпү. *--- ә язгы уйнак җил җирнең бу дымлы сулышын авыллар өстенә алып китә, ислемай өләшкәндәй, кешеләргә һәм хайваннарга сирпеп йөри.* Ә.Еники

**Сирпеп карау** Сирпергә тырышу; нәтиҗәсен белү өчен сирпү. *Тыйнак, тотнаксызлыкны җене сөйми, егетләргә күз сирпеп тә карамый.* З.Мәхмүди

**Сирпеп китү** Бик аз гына яки үтеп барышлый сирпү. *Ул тагын тирән кичерешләр белән изаланды, әйтерсең лә аз гына сирпеп киткән яктылык та сүнде, һәм тирә-як тагы дөм караңгылыкка чумды.* А.Расих

**Сирпеп кую** Бер мәртәбә сирпү. *Зөһрә ханым, елмаеп, миңа хәйләкәр генә күз сирпеп куйды ---.* Ә.Еники.

*Ирләр сүзенә кысылмыйча, тик кенә утырсаң ни була дигәндәй, бер күз сирпеп кенә куйды.* Л.Ихсанова

**Сирпеп тору** Туктаусыз, берөзлексез сирпү. *Толстойныкы шикелле, саллы кушма җөмләсе артында, пеләш башын елтыратып, көлемсерәп, җылылык сирпеп торган автор образын сиземләве кыен түгел.* Т.Галиуллин. *--- кояш яктысында ниндидер серлелек сирпеп торган тузганактан меңләгән вак парашютчыклар аерылды да, десантчылар шикелле, дәррәү болын өстенә сибелде.* Җ.Дәрзаман

**Сирпеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр сирпү. *Безнең өйгә генә керә алмый җеннәр: --- әби, бисмилла әйтеп, бөтенесен куш кулы белән сирпеп чыга.* Г.Гобәй

**СИРТМӘ** *и.* 1) Тартканда сузыла һәм яңадан кире кайта торган сузылмалы нәрсә, пружина. *Бернәрсәгә дә исе китмәгәндәй утырган солдат, кинәт кенә сиртмәгә баскандай сикереп, уртага ыргылды.* К.Нәҗми. *Назыйм абый дигәне алгарак барып, бөтен сиртмәләрен шыгырдатып, диванга утырды.* Г.Кашапов

2) Коедан су күтәрү өчен, алгы башына чиләк, икенче башына авыр йөк тагылып, кое баганасына аркылы беркетелгән юан колгадан гыйбарәт җайланма. *Авылның аргы очындагы урам коесының сиртмәсен шыгырдата-шыгырдата су чыгаручы ак алъяпкычлы хатыннар күренде.* М.Әмир. *Коеның сиртмәләрен шыгырдата-шыгырдата су чыгарганда да, өйгә кайтканда да Гөлбану --- туктамый елады.* Г.Ибраһимов

3) Тарантас, арба һ.б.ш.ларның хәрәкәтен йомшарту өчен, агач колга, тимер тасмалар яки башка шундый сыгылмалы материалдан ясала, көчәр белән козау арасына ныгытыла торган җайланма, рессор. *Каретада ике кешелек урын, алар тире каешларга беркетелгән. Ул каешлар сиртмә функциясен дә үтиләр.* Мирас

4) *диал.* Тарантас. *Сабантуйга барганчы, урамда хәрәкәт кызулана: сиртмәләргә төялеп, чатыр чабып инде китә дә башлыйлар.* М.Мәһдиев

5) *к.* **силә** (*1 мәгъ.*). *Каен сиртмә, кайры бишек – Безне шулар үстергән.* Г.Мөхәммәтшин. *Кабыктан ясап бирделәр безгә дугалы бишек, Миләш сиртмәгә элделәр, бауны юкәдән ишеп.* З.Нури. *Чаршауның теге ягында сиртмә шыгырдый башлады. Шундук, мазасызланып, яшь бала еламсырарга тотынды.* Г.Бәширов

**СИРТМӘКОЙРЫК** *и.* 1) *зоол.* Селкенчә, чәберчек. *Каядыр барышлыймы, каяндыр кайтышлыймы, койма такталарына сиртмәкойрыклар кунгалап, берсе – бер, икенчесе икенче якка оча.* Р.Гариф

2) *күч.* Җилбәзәк хатын-кыз. *Ике тәүлек буе кунакны һәм аның сиртмәкойрыгын сыйлар өчен, шактый чыгым тотылды.* Х.Камалов

**СИРТМӘЛЕ** *с.* 1) Сиртмәсе булган, сиртмә белән эшләнгән. *Сиртмәле кое янында бер төркем агай-эне боз каткан улаклардан ат эчереп торалар.* И.Гази. *Бөтен өйдә агач сиртмәле кабык бишектән, иске самавыр белән агач табактан --- башка күз төшерерлек берни дә юк иде.* Г.Бәширов

2) *күч.* Кое сиртмәсенә охшаган, бер күтәрелә, бер төшә торган. *Җитмәсә, нәкъ юл читендә генә, чыгырларын шалтыратып, сиртмәле скважина эшләп тора.* А.Хәсәнов

**СИРТМӘЛЕК** *и.* **1.** Сиртмәгә ярарълык материал (агач, пружина һ.б.ш.). *Карама төбенә әти килеп Карап торган имеш, шикләнеп. Тик карама аны читләтмәгән: – Мә балаңа, дигән, сиртмәлек.* М.Сөндекле

**2.** *с. мәгъ.* Сиртмәгә ярарлык, сиртмә ясарга дип билгеләнгән. *Сиртмәлек агач эзләү*

**СИСКӘНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сискәнү**

2) Сагайту, куркыту, шомландыру. *Донослар хөкүмәт органнарын сискәндерә, охранканың колагын торгыза.* И.Нуруллин. *Дәһшәтле яңгыраш Җаекка да килеп җитә, ил күгенә төшкән кан шәүләсе җаеклыларны да сискәндерә.* Мирас

**Сискәндереп җибәрү** Кинәттән сискәндерү. *Барыена карата бу тәкәббер картның әле һаман да болай һавалы торуы аны тагын сискәндереп җибәрде.* Ф.Хөсни. *Әтинең кискен һәм усал әйтелгән сүзләре барлык кешене --- сискәндереп җибәрде.* Р.Низамиев

**Сискәндереп кую** Көтмәгәндә сискәндерү. *Әмма сугышның һәм авылдагы ачлыкның иң авыр бер вакытында Әсма карчыкның акылы ялгышу халыкны сискәндереп куйды.* М.Мәһдиев

**СИСКӘНҮ** *ф.* Кисәк, көтелмәгән берәр нәрсәдән курку тойгысы кичерү, куркып кую. *Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни.* Г.Тукай. *Василий һич сискәнмәде, курыкмады, бер хәрәкәт ясамады, ә немецларга карап катты да калды.* Ә.Еники

**Сискәнеп китү** Кинәт сискәнү. *Шундый уйлар белән катып торганда, команда тавышына сискәнеп китеп, тирә-ягына карады.* М.Гафури. *Безнең колын --- бик куркак. Берәрсе катырак кычкырып җибәрсә я шакылдап капка ябылса, дерт итеп сискәнеп китә.* Г.Бәширов

**Сискәнеп кую** Бер мәртәбә сискәнү. *Сәлим шундый каты кычкырды: Акбүз дә куркып сискәнеп куйды.* Г.Гобәй. *– Газетага? Кайсы газетага? – дип кинәт сискәнеп куйды директор.* Э.Касыймов

**СИСКӘНҮЛЕ** *с.* 1) Сискәнүне белдерә, чагылдыра торган (караш, хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Муса, чәчләре үрә торгандай, сискәнүле караш белән аңа текәлде.* Ш.Маннур

2) Сискәнү белән барган, сискәнү катыш булган. *Бик озак көрсенеп, азапланып ятты ул, өй бөркү булгангамы, йөрәге янганга күрәме, өстеннән калын юрганны да аягы белән ачып ташлады, һәм аның авыр уйлардан шешенгән башы ничектер бер арада тынгысыз, сискәнүле йокыга талды.* Ә.Еники. *Шагыйрь, серле, тылсымлы, сискәнүле мәхәббәт юлының озынлыгын, җаваплылыгын искә төшереп, үз бәхетеннән көнләшеп тә куя бугай.* Т.Галиуллин

**СИСКӘНҮЧӘН** *с.* Сискәнеп китүчән. *Бик тиз сискәнүчән, куркак җанга әверелгән идем.* Безнең гәҗит. *Сискәнүчән кеше. Сискәнүчән бала*

**СИСТЕ́МА** *и. гр.* 1) Ниндидер тулы бербөтен, бергәлек тәшкил иткән, үзара

бәйлелектә торган элементлар күплеге; әлеге элементларның урнашуындагы билгеле тәртип. *Тора-бара Габдулла Тукай халык авыз-поэтик иҗаты әсәрләрен җыю, системага салу һәм бастырып чыгаруның җитди һәм кирәкле эш икәнен төшенеп алган.* И.Нуруллин. *Киштәдәге китаплар билгеле бер системада урнаштырылган*

2) Үзара эзлекле бәйләнештә булган элементлардан торган бербөтеннең структурасы, төзелеше. *Әгәр безнең нерв системабыз шулай тиз сизә ала торган итеп төзелгән булса, безне урап алган дөнья танымаслык дәрәҗәдә үзгәреп күренер иде.* Я.Перельман. *Тик алай да кешене хайваннардан аерып торучы мөһим бер система бар, ул – үзәк нерв системасы.* Р.Нуруллин. *Югары төзелешле үсемлекләр системасы*

3) Рәсми рәвештә бер үзәк карамагында булган оешмалар, учреждениеләр. *Милли мәгарифнең тулылыгын һәм өзлексезлеген саклау максаты белән, милли мәктәп тулы бер система булып оеша.* И.Әмирхан. *Сәламәтлек саклау системасы. Банк системасы. Фәннәр академиясе системасында эшләү*

4) Нәрсәнедер оештыру формасы, нәрсәнедер эшләү-эшләтү, якын килү үзенчәлеге. *Казан ханлыгы чорында өч басулы система киң таралган, кайбер урыннарда, ышна җире ачып, җир эшкәртү тәртибе дә сакланган.* Б.Хәмидуллин. *Иң борынгы система булып урманнарны яндырып иген чәчү, ягъни утлавык системасы торган.* А.Фәткуллин. *Эш хакы системасы. Торак белән тәэмин итү системасы*

5) Иҗтимагый төзелеш формасы, строй. *Хәлләр берникадәр СССР һәм социалистик система җимерелгән вакыттагыга охшаган, шул ук вакытта аннан кискен аерыла да.* Б.Гатин. *Феодаль система. Капиталистик система*

6) Идарә итү ысулы, формасы. *Ибраһим Салаховта да тоталитар система үзбаш фикер йөртә алучыны күрә.* Г.Ахунов. *Җәмгыятьтәге кимчелекләр, административ-бюрократик система я турыдан-туры, я Эзоп теле ярдәмендә тәнкыйть ителә.* Ә.Закирҗанов. *Шул рәвешле, илдә ике партияле сәяси система урнашырга мөмкин.* Ф.Уразай

7) Шәхестән, җәмгыятьтән аермалы буларак, дәүләт, рәсми оешмалар. *Янә шуларга өстәп тагын бик мөһим бер нәрсәне әйтергә кирәктер: халыкны система белән килештерә торган ниндидер бер бөек идеал да булырга тиеш.* Ә.Еники. --- *күп кенә чын офицерлар атылып үлгән икән! Система белән турыдан-туры каршылыкка кергәннән соң, үзләренең көчсезлеген аңлаганнан соң шулай эшләгәннәр инде ул бичаралар!* М.Вәлиев

8) Билгеле мөнәсәбәтләргә, күренешләргә карата гомуми кабул ителгән тәртип. *Театрда абонемент системасы. Еллык яллар системасы. Хезмәткәрләрне аттестацияләү системасын кертү*

9) Уйланылган план, эш итү тәртибе; төрле эшләрнең, чараларның үткәрелү, башкарылу тәртибе. *Ул үз системасы белән эшли. Материаллар белән эшләү системасы*

10) Берәр тәгълимат, күзаллау, караш нигезендә яткан принциплар җыелмасы. *Платон системасы. Ушинскийның педагогик системасы*

11) Нәрсәләрнең дә булса гомуми классификациясе, берәр принципка таянып төркемләү; уртак бер билгесе нигезендә берләштерелгән өлешләр, берәмлекләр, элементлар җыелмасы. *Химик элементларның периодик системасы. Тартык авазлар системасы. Халыкара берәмлекләр системасы*

12) Берәр эшчәнлек өлкәсендә гамәлдә сыналган ысулларның, алымнарның барысы. *Күрәсең, Метерлинк төзегән эстетик система нәкъ менә әдәбиятка нәфислек алып килүе ягыннан Коганны җәлеп итә.* Д.Заһидуллина. *Станиславский системасы. Йоглар системасы нигезендә гимнастика белән шөгыльләнү. Тәрбияләү системасы. Йөрәк авыруларын дәвалау системасы*

13) Нәрсәнедер башкаруның кагыйдә, таләп һ.б.ш.лар җыелмасы. *Мин аның яртысын аңламадым да инде: силлабик система ни дә силлабо-тоник система ни анда – аермыйм, белмим, ләкин кайбер нәрсәләрне чамалый башладым.* Р.Фәйзуллин. *Әгәр өч баллы система булса, мин бу әсәрләргә уртак бер билге куяр идем – икеле! Биш баллы система булгачтын, мин өчле куям.* Р.Батулла

14) *тех.* Бер максатка хезмәт иткән, үзара бәйләнгән җайланма, корылма, машина, механизм һ.б.ш.лардан торган техник комплекс. *Бакчага таба тар гына улак сузыла – монысы үзенә күрә шундый сугару системасыдыр инде, күрәсең.* Р.Төхфәтуллин. *Бу подъезд, фатирларга тимер ишекләр куябыз, сигнал системалары булдырабыз.* Мәдәни җомга. *Автоматлаштырылган идарә системасы. Җылыту системасы*

15) *информ.* Компьютер ресурслары белән идарә итү һәм кулланучы белән элемтәгә керү өчен хезмәт итә торган үзара бәйле программалар комплексы. *Компьютерга апгрейт ясау уңайлырак, чөнки аның система блогында урын күп (апгрейт – системага яңа эчке җиһазлар урнаштыру).* Д.Сәфәров. *Операцион система*

16) Эзлеклелек, закончалык. *Төрки телләр белән монгол һәм тунгус-маньчжур телләре үзара генетик туганнар дип исәпләнелә. Әгәр шушы телләрдәге гади саннарны чагыштырып карасак, монда бернинди закончалык һәм система таба алмаячакбыз.* Н.Фәттах. *Образларында билгеле бер тәртип, система ачык сиземләнә ---.* Ф.Ганиева

17) *тех.* Берәр техник җайланма, корылманың тибы, маркасы, конструкциясе. *Ленин инициативасы белән, Көнбатыштан илгә беренче автомат элемтә системасы кайтартыла.* Р.Мөхәммәдиев. *Калашников системасы автоматы. Яңа система самолёты*

18) Бербөтен су юлы тәшкил иткән табигый һәм ясалма сулыклар; кушылдыклары белән бергә каралган елга. *Идел системасы. Днепр системасы*

19) *геол.* Тау токымнарының уртак бер казылма флора һәм фауна белән характерлана торган катламнары

20) Ниндер бер эш, функция өчен билгеләнгән күп төрле предметлар, әсбаплар җыелмасы. *Катлаулы краннар системасы. Чәч тарау өчен тараклар һәм щёткаларның тулы бер системасы*

21) Берәүнең шәхес буларак карашларыннан, күзаллау, фикер, ышанулары һ.б.ш.лардан торган бербөтен. *Фәнни төшенчәләрнең тулы системасы формалашу. Карашлар системасы. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр системасы*

22) *сөйл.* Нәрсәнеңдер гадәтләнгән тәртибе, җае, көе; гадәти хәл. *Әгәр дә ул үзе корган система буенча яшәмәгән булса, ихтимал, яшьли киткән булыр иде.* Р.Батулла. *Эшчеләрнең сөйләшүләре буенча, монда система болайрак: хезмәткәрне бер ай сынап карау срогы белән алалар.* Р.Хажиев. *Бәяләре арттканга исе китми Тайфунның – анысы система аның хәзер.* Җ.Юныс

23) *сөйл.* Сыек дәвалау матдәләрен организмга тамчылап, дозалап кертү җайланмасы. *Ул, системасын минем карават кырыена куеп: – Я, иптәш Яруллин, әзерлән, кан җибәрәбез, – диде.* Ф.Яруллин. *Аның бу сүзләрен ишетүгә, кош тоткандай, Зәнфирә сумкасын ачты һәм аннан система куя торган әйберләрен чыгарды.* Ф.Садриев

**СИСТЕ́МАЛАШТЫРУ** *ф.* Системага (*1 мәгъ.*) салу, тәртипкә китерү. *Менә шушы дөньякүләм идеологик акциядән соң язучылар мохитен – шул 70 еллык чорны – ничегрәк итеп системалаштырырга соң?* Р.Фәйзуллин. *Укучыларның белемнәрен системалаштыру*

**Системалаштыра бару** Эзлекле рәвештә, әкренләп системалаштыру

**Системалаштыра башлау** Системалаштырырга тотыну

**Системалаштыра килү** Электән үк системалаштыру

**Системалаштырып бетерү** Тулысынча системалаштыру; тәмам системалашкан хәлгә китерү

**Системалаштырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, тулысынча системалаштыру

**Системалаштырып тору** Даими рәвештә системалаштыру белән шөгыльләнү

**СИСТЕ́МАЛАШУ** *ф.* Система буларак формалашу, система рәвешенә керү

**Системалаша бару** Торган саен ныграк системалашу. *Моңа бәйле рәвештә, шагыйрьнең әдәбиятта халыкчанлык турындагы карашларының һаман тирәнәя, системалаша баруы күзәтелә.* И.Нуруллин

**Системалаша төшү** Беркадәр системалашу

**Системалашып бетү** Бөтенләй, тулысынча системалашу

**Системалашып җитү** Тиешле дәрәҗәдә системалашу

**СИСТЕ́МАЛЫ** *с.* **1.** Системага нигезләнгән, системасы булган; тәртипле. *Аңа берәү дә яшьтән системалы белем алып --- музыкант булырга юл күрсәтмәде.* М.Җәлил. *Яза-яза үзең дә төшенерсең әле, ә хәзергә сиңа иң кирәге – системалы белем.* Ф.Яруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Системага салып, тәртипле рәвештә, тәртибен белеп. *Ринат әфәнде сүзләрем белән килешеп һәм киләчәктә милли эшләрне фәнни дәрәҗәдә, системалы һәм максатчан алып барырга кирәклеге белән ризалашты.* Ф.Бәйрәмова. *Хисамов әлеге әсәрне озак еллар дәвамында системалы өйрәнеп, әдәбият фәнен җитди казанышлар белән баета.* Ә.Закирҗанов

**СИСТЕ́МАСЫЗ** *с.* **1.** Билгеле системага нигезләнмәгән, системасы, эзлеклелеге җитмәгән яки бөтенләй булмаган; тәртипсез. *Ул вакытта Президентның әңгәмәдәшләре Илбашына системасыз оппозиция, Михаил Ходорковский эше һәм Дербент шәһәрендәге сайлауларда булган гауга турында «уңайсыз» сораулар бирде.* Ватаным Татарстан. *Системасыз тикшеренүләр*

**2.** *рәв. мәгъ.* Билгеле системага таянмыйча; система сакламыйча, тәртипсез рәвештә; системалаштырмыйча. *Вакыты юклыктан, егет аларны өстәнөстән генә, берниндi системасыз, башына килгәнчә яза да чыга иде.* Ф.Яхин

**СИСТЕ́МАСЫЗЛЫК** *и.* Берәр күренештә, эш-гамәлдә система, тәртип, эзлеклелек җитмәү яки бөтенләй булмау күренеше; системасыз, тәртипсез булу хәле. *Секцияләрнең эшендә бүленеп-бүленеп эшләү, системасызлык, тукталып эшләү күзгә бәрелә.* М.Җәлил. *Бу мине системасызлыктан коткарып кына калмады, бу мине үзем язачак әсәрләргә карата да саграк булырга, тел-сурәтләү чараларына таләпчәнрәк килергә өйрәтте.* Г.Ахунов

**СИСТЕМА́ТИК** *с.* Систематикага (*2 мәгъ.*) караган. *1950 елда Ботаникларның халыкара конгрессында теләсә нинди дәрәҗәдәге систематик берәмлекне таксон дип атарга тәкъдим ителде.* Л.Мәүлүдова

**СИСТЕМА́ТИКА** *и. гр. махс.* 1) Күптөрле нәрсәләрне классификацияләү, төркемләү. *Кристаллар систематикасы. Изотоплар систематикасы*

2) Ботаниканың яки зоологиянең барлык хайваннарны, үсемлекләрне төрләре, ыруглары, семьялыклары буенча классификацияләү, төркемләү, тасвирлап бирү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Хәзерге вакытта систематика үсемлекләрнең күптөрлелеген генә түгел, бәлки аларның килеп чыгышын, тарихи үсешен һәм ырудашлык мөнәсәбәтләрен дә өйрәнә.* Л.Мәүлүдова. *Аларның классификациясе, ягъни охшашлыклары һәм ырудашлыклары нигезендә төркемнәргә бүлеп системалаштыру белән биологиянең систематика дигән өлкәсе шөгыльләнә.* Биология

**СИТАР** *и. фар.* 1) Корпусы ярымтүгәрәк формасында булып, уң кулның баш һәм имән бармагы белән чиртеп уйнала торган, озын саплы, өч кыллы уен коралы

2) Түгәрәк корпуслы, сабында өстәмә резонаторы булган, чиртеп уйнала торган җиде кыллы уен коралы. *Һинд классик музыкасын ситарда уйнап башкаралар*

**СИТРО** *и. фр.* Алкогольсез газлы эчемлек: җимеш суы

**СИТСЫ** *и. голл.* **1.** Тоташ бер төсле яки басма бизәкле юка киже-мамык тукыма. *Килгән саен Гыйльменисаның кызлары әле үзенә яулыкмы, алъяпкычлык ситсымы кыстыра киләләр.* Ф.Хөсни. *Сак-Сок бәетен рәсемнәр белән бизәп басалар. Бу рәсемнәр хәтта Казанда чыккан ситсыларга да тукыла торган була.* И.Надиров

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. --- *минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда --- төрле төстәге хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүш булганга, бу*

*Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.* И.Нуруллин

**СИТУАТИВ** *с.* Аерым бер ситуациягә караган, билгеле шартлар белән чикләнгән. *Ситуатив һәм баллистик экспертизалар, тикшерүче үткәргән чаралар, шаһитлар күрсәтмәләре алар файдасына булмый.* Безнең гәҗит. *Ситуатив модельләр*

**СИТУА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Төрле шартлар, мөмкинлекләр, мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә туган хәл; вазгыять. *Хәмит бу хәлләргә каршы, әмма шушы ситуациядән чыгу юлын таба алмый.* Ф.Бәширов. *Г.Ибраһимов белән ул [Тукай] күпчелек очракта фельетон телендә бәхәсләшә. Оппонентын көлке ситуациягә куя яисә берәр уңышсыз гыйбарәсен эләктереп ала.* Казан утлары

**СИ́ФИЛИС** *и. лат.* Спирохета китереп чыгара торган, эчке әгъзалар, сөякләр, нерв системасын зарарлый торган венерик авыру. *Ак халатлы теш арасыннан гына утлы сүзләрне чәчте: «Урындагы кешеләрне аздырып, сифилис таратып йөрисеңме әллә син?»* Мирас

**СИФОН** *и. гр.* 1) Сыекчаларны бер савыттан икенче савытка бушату өчен кулланыла торган кәкре көпшә

2) Газлы су ясау һәм саклау өчен хезмәт итә торган бормалы көпшәле шешәгә охшаш савыт

3) *геогр.* Җир асты карст елгасы каналының вертикаль яссылыкта күренгән буынсыман бөгелеше

4) Плотинадан су ташлау өчен, буа аркылы үткәрелгән торбалардан гыйбарәт җайланма. *Ә андый күләмдәге су бары тик буаны җимереп кенә бәреп чыга алган булыр иде, әмма сифон тишегеннән ул кадәр су агып чыга алуына ышану авыр.* Шәһри Казан

**СИХӘТ** *и. гар.* Саулык-сәламәтлек өчен файдалы тәэсир, шифа, файда. *Мунча, мунча! Җанга рәхәт, тәнгә сихәт биреп, гомерне озайта торган урын.* А.Гыйләҗев. *Шагыйрь сүзе мең җәрәхәтне төзәтерлек сихәткә ия булса да, хәзергесе көндә шигырь язып кына көн итүе мөмкин түгел.* Т.Галиуллин

**СИХӘТЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* Савыктыру, сәламәтләндерү. *Безгә сырхау иңде бит әле. Догалар белән сихәтләндерсәң икән син аны.* Н.Гыйматдинова. *Тик дәвалау очраклары һәрвакыт төрле. Һәр кешенең үзенә туры килгәнен сайлап алып сихәтләндерергә тырышабыз.* М.Нурулла

**Сихәтләндерә бару** Көннән-көн ныграк сихәтләндерү

**Сихәтләндерә төшү** Бераз сихәтләндерү; тагын да сихәтләндерү

**Сихәтләндереп җибәрү** Кинәт кенә сихәтләндерү. *Әйтерсең лә җир катламы күмеп торган чишмәне кемдер тазартып куя, аннан тирә-якны сихәтләндереп җибәргән саф су бәреп чыга.* Т.Галиуллин

**СИХӘТЛӘНҮ** *ф.* Сәламәтләнү, савыгу. *Кунак кызы йомшак тавыш белән Файзуллага дәште: – Нихәлләрең бар соң, Файзулла абый? --- Тизрәк сихәтләнә күр инде!..* Г.Бәширов. *– Хушыгыз, тизрәк сихәтләнегез, – дидем дә чыгып киттем.* Ф.Садриев

**Сихәтләнә бару** Торган саен ныграк сихәтләнү

**Сихәтләнә башлау** Хәл сихәтләнүгә табан үзгәрү. *Ул үзе дә, кызларын күрү шатлыгыннан булса кирәк, тизрәк сихәтләнә башлады.* Р.Сәгъди

**Сихәтләнә төшү** Бераз сихәтләнү; тагын да сихәтләнү. *Тик бераз сихәтләнә төшкәч кенә тутайны далага алып чыга башладылар.* Р.Батулла

**Сихәтләнеп җитү** Бөтенләй сихәтләнү

**Сихәтләнеп килү** Әкренләп сихәтләнү

**Сихәтләнеп китү** Тиз арада сихәтләнү. *Ул, кайгыртучанлык күрсәтеп, хәзер инде бераз тынычлап ял итегез, бөтенләй сихәтләнеп китәрсез, диде.* М.Шабай. *Иртәгә мунча ягарбыз, тәннәрегез бер сихәтләнеп китәр.* Н.Хәсәнов

**СИХӘТЛЕ** *с.* Саулык-сәламәтлек өчен файдалы, шифалы. *Әмма Газизә абыстай бирешмәде: – Барын бардыр да, тик өй ашы тәмлерәк тә, сихәтлерәк тә.* Г.Шәрипова. *Йөзеңне җылы кояшның назлы, сихәтле нурлары иркенә куясың.* И.Диндаров

**СИХӘТЛЕК** *и. ялг. к.* **сихәт**. *Аллага сыенасылары килми мөртәтләрнең, дөньякүләм табибларга, сихәтлек серләрен белүче академикларга сыеналар.* Ф.Баттал. *– Иң әүвәл анаңның сихәтлеге турында кайгырт, серне читләргә ачма, – диде.* Ә.Моталлапов

**СИХӘТЛЕЛЕК** *и.* 1) Саулык-сәламәтлек, сау-сәламәт булу халәте. *Инде алдагы гомер юлында кадер-хөрмәткә күмелеп, фани дөньяларның рәхәтен татып, күңел тынычлыгы, тән сихәтлелеге белән, авырмыйча, безгә – балаларыңа терәк һәм үрнәк булып, оныкларыңның да миһербанын тоеп яшәргә язсын.* Безнең гәҗит

2) Файдалы булу, кирәклек, файдалылык. *Тау һавасының сихәтлелеге*

**СИХӘТСЕЗ** *с.* Сау түгел, саулыгы булмаган, чирле

**СИХӘТСЕЗЛЕК** *и.* Сау, таза булмау хәле, саусызлык. *Сихәтсезлегем аркасында менә шушында торып калдым бугай.* Ф.Хөсни

**СИХЕР** *и. гар.* 1) Гайре табигый булып тоелган ысуллар кулланып, гадәттән тыш күренешләр булдыру. *Ислам диненең сихергә һәм сихерчеләргә каршы булуы «Бәкарә» сүрәсенең 102 нче аятендә аеруча ачык чагыла.* А.Тимергалин. *Аждаһалар тегенди-мондый сихер белән йоклатып калдырмасыннар дип, билбавы белән каенга үзен бәйләп куйган.* Ф.Яруллин

2) Табигать законнары белән сыешмаган күренешләрне булдырырга ярдәм итә торган серле магик алымнар, ысуллар, чаралар. *Анасы Сабира Закирга һаман әйтә иде: «--- Алар бөтен нәселләре белән сихерче, алар шул сихер белән генә дөньяда торалар, сине шул бозды...»* Г.Ибраһимов. *Теге кеше капкага корылган ак җәймәгә сөяп утырта иде дә, ящиктан чыккан бер чыбыкның башын тотып, иреннәрен кыймылдата иде. Кара Чыршы халкы моны сихер укый дип белә иде.* М.Мәһдиев

3) *миф.* Сихер (*1 мәгъ.*) көче белән барлыкка китерелә торган халәт, рухи хәл, сыйфат. *Егет сихереннән айныды. Торып караса, ни күрсен: кычыткан арасында аунап ята.* Әкият

4) *күч.* Берәр нәрсәнең яки кешенең күңелне нык җәлеп итә, кызыксындыра торган үзлеге, сыйфаты, асылы;

тылсым, сер. – *Инде... – Кече инәем сәер генә көлеп куйды. – Шулкадәр дә сихерләр икән берәүне берәү. – Ирем кисәге – итем кисәге. Бар сихере шунда.* М.Кәрим. *Ник күңелем һаман аңа гына омтыла? Ниндидер сихер кебек бу?* Х.Камалов

5) *күч.* Гаҗәпләнерлек, искитәрлек нәрсә, могҗиза. *Бүген бәйрәм. Корбан бәйрәме. Күпме заманнар мин акрын гына якынлашып килгән шушы иртәнең сихере астында яшәдем.* М.Кәрим. *Адәм баласы тормышта һәрвакыт матурлыкка омтылып, рухи бер идеал, ниндидер бер сихер-могҗиза көтеп яшәр өчен яратылган!* Р.Хисмәтуллин

**СИХЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Сихер (*1–3 мәгъ.*) тәэсиренә дучар булу. *Хатынкызларның кайберләре, сихерләнгән шикелле, койма буйлатып артыннан баралар.* Г.Бәширов

2) *күч.* Әсәрләнү, бик нык тәэсирләнү. *Алтынчәч Котдусованың сәхнәдә күренүе һәм сандугач тавышлары белән җырлап җибәрүе була, тамашачылар шундук сихерләнә, аңардан күзен дә ала алмый.* Мирас

**Сихерләнеп бетү** Бөтенләй сихерләнү

**Сихерләнеп калу** Сихерләнгән хәлгә килү

**Сихерләнеп тору** *к.* **сихерләнеп калу**. *Бераз шул гүзәллеккә сихерләнеп тордым да гармун моңы ишетелгән якка таба атладым.* Н.Дәүли

**СИХЕРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Сихер ярдәмендә тәэсир итү, берәр нәрсәгә яки кешегә нинди дә булса сыйфатны бирү. *Белəм инде: мине әсир итәрсең, сихерләрсең, мине әфсүн итәрсең.* Г.Тукай. *Ходай белсен, әллә нинди хәл инде аларның... Аларны сихерләгәннәр, бозганнар, диләр.* Г.Ибраһимов. *Карак Моратшаның, әйткәнебезчә, әүрәтү, сихерләү сәләте бар иде.* М.Кәрим

2) *күч.* Нәрсә белән дә булса әсәрләндерү, гаҗәпләндерү. *Андагы уен коралларының күплеге һәм төрлелеге аны сихерли.* Г.Ахунов. *Шушы көй Миләүшәне әсир итте дә инде. Сихерләде.* Сөембикә

3) *күч.* Үзенә карату, җәлеп итү. *Ат көтүчесе Усман дигән егет Гөлйөземнең күңелен бик яшьли сихерләде; ике ел йөргәч, шуңа кияүгә дә чыгып куйды.* Г.Ибраһимов. *Бер көн эчендә Әсгать мине бөтенләй сихерләде, моннан ары без ташлашмас дуслар булдык.* М.Кәрим. *Тыңлаучыларны Солтангалиев шул тикле ышандырган, сихерләгән иде ки, --- мәйдан берара тын алырга да уңайсызланып торды сыман.* Р.Мөхәммәдиев

**Сихерләп алу** Тиз арада сихерләү. *Син шулай дидең дә --- бер авыз сүзең белән әле генә бөтен дөньяны сихерләп алган моңны сүндердең.* М.Кәрим

**Сихерләп бетерү** Барысын да сихерләү; нык сихерләү, тәмам сихерләү

**Сихерләп тору** Дәвамлы рәвештә сихерләү

**Сихерли бару** Торган саен ныграк сихерләү. *Класс бүлмәсендә Мәскәү татарының көчле бәрхет тавышы яңгырап-яңгырап китә, бөтен күзләр аңа текәлгәннәр, ә ул классны сихерли бара.* М.Мәһдиев

**Сихерли башлау** Сихерләргә тотыну. *Шаһмара шундук сихерли башлады. Салия кинәт аккош булып калды.* Р.Батулла. *Карчыклар аны сихерли башладылар: битенә, шәрә тәненә ниндидер ак, кара ташлар белән сызыклар сыздылар, өстенә көл сиптеләр, әллә нинди үләннәр белән йөзен чәбәкләделәр.* Г.Гыйльманов

**Сихерли бирү** Бернәрсәгә карамастан сихерләү

**СИХЕРЛЕ** *с.* 1) Сихерләү (*1 мәгъ.*) көченә ия булган, сихерләү (*1 мәгъ.*) сәләте булган. *Батырша белән бәйләнергә дә куркалар. Имеш, аның әллә нинди сихерле карчыклары бар. Ул шулар аркылы терлекне агулый, имеш.* Ф.Сәйфи

2) Сихер көченә ия булган, тылсымлы. *Теге томаналар шушы уенның күп заманалар үткәч хоккей дигән тетрәткеч сихерле исемгә ия булачагын алдан күрә белмәгәннәр.* М.Кәрим

3) Сихерләнгән, сихер тәэсиренә дучар ителгән. *[Гатау:] Сихерле чаршаулармы соң ул, селкенә дә тора.* М.Фәйзи. *Урман тулы халык, сихерле йокыга батып, колактан калды, зиһеннән язды.* М.Кәрим

4) *күч.* Күңелне нык тарта, җәлеп итә, яраттыра торган. *Ләкин күзләрнең явын алып янган ул сихерле утка барып җитә алмадым, ул кинәт сүнде.* Н.Дәүли. *Сихерле тавыш. Сихерле елмаю*

5) *күч.* Гадәти булмаган, серле. *Меңләп йолдыз, үзләренең фосфорлы ялтыравыклары белән төннең караңгы күгендә елтырап, җиргә сихерле яктылыклар коялар.* Ф.Әмирхан. *Мин дә киттем, күз нурына тартылып, сәрхуш булып, Шул сихерле дүнгәләктә коршалып, мәхбүс булып!* Ш.Бабич. *Егетнең йөзе, карашы бөркетне хәтерләтә – нык, кырыс, горур, серлесихерле.* Ф.Бәйрәмова

**СИХЕРЧЕ** *и.* Сихер белән шөгыльләнүче кеше; әфсенче, арбаучы, күз буучы. *Хатынга кемдер: «Сихерчегә төн уртасында барырга кирәк, сорап, ишек кагып тормыйча, туры басып керергә кирәк», – дигән иде.* Г.Ибраһимов. *[Нурислам:] Юк, хәбәрче түгел, кош сыйфатына кергән сихерче, явыз заттыр бу, мөгаен.* М.Кәрим. *Их, сихерче булсаң икән дә менә хәзер табигатьнең шушы гүзәл почмагында шифалы сулышыңны өрсәң икән.* Р.Мөхәммәдиев

**СИХЕРЧЕЛЕК** *и.* Сихерче кәсебе, сихерче шөгыле

**СИХРИ** *с. гар.* 1) Сихерли торган; сихерләнгән. *Сихри күздән сихри уклар атылсыннар.* Ш.Бабич. *Нурислам яхшы белә: сихри көч алдында куркырга да, чигенергә дә ярамый.* М.Кәрим

2) *күч.* Күңелне били торган, нык тәэсир итүчән. *Рухия елганың аргы ягында --- басып тора, ләкин йөзендә гадәттәге сихри елмаю юк иде.* В.Нуруллин. *Әти-әнисе үлгән көнне күңелендә туган сихри аһәң соңыннан мәхәббәт борчуларыннан туып торган икән.* Сөембикә

3) *күч.* Серле, тылсымлы, сокландыра торган. *Ә күк йөзе шундый чиста, исең китәрлек сихри төскә – аксыл зәңгәр төскә кергән.* Р.Мөхәммәдиев. *Салават күперенең сихри матурлыгы кемнең генә күңелен әсир итмәс икән.* Шәһри Казан

**СИХРИЛЕК** *и. юг.* Тылсымлылык; серлелек. *Аннары кемдер урындыкны шыгырдатып куйды, кемдер*

*авыр күрсенде: сихрилек юкка чыкты.* Г.Шәрипова

**СИШӘМБЕ** *и. фар.* Календарь атнаның дүшәмбедән соң килә торган икенче көне. *Мишәрчә сөйләмдәге «буш көн» сишәмбенең иң борынгы атамаларыннан санала. Кайбер ырымлы картлар сишәмбе көнне хәзер дә әле юлга чыгудан тыелып калалар.* В.Беркутов

**СИЮ** *ф.* Организмда җыелган сидекне чыгару. *Нәрәт алу өчен, сержант алдында юри казарма диварына сигәнем бар.* З.Мәхмүди. *Ничә малай шуның [председатель] аркасында тотлыга торган яисә астына сия торган булып калды.* Р.Мөхәммәдиев

**Сиеп алу** Тиз генә сию

**Сиеп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә сию. *Нәрсә эшләгәннәрдер, бер мәлне кызлар кызыксынган җир ачытып, авыртып алды, һәм мин сиеп җибәрдем.* Ф.Яруллин

**Сиеп йөрү** Озак вакыт дәвамында сию. *Тәнгә яңа тире үсеп чыкканчы, астыма сиеп йөрдем.* З.Мәхмүди

**Сиеп кую** Тиз генә сию. *Егетләр бала тугач, ул елый, сиеп куя дип, бу мәшәкатьләрдән куркып, түзә алмыйча, гаиләдән китә.* Безнең гәҗит

**Сиеп тору** Әле, хәзерге вакытта сию

**Сия башлау** Сияргә тотыну. *Бер мәлне Халисәләрнең сыерының муенында кан эзе күренде, ә икенче көнне ул кан сия башлады да бераздан егылып үлде.* М.Кәбиров

**Сия бирү** Бернәрсәгә карамастан сиюне дәвам итү

**СИЯҺ** *с. фар. иск.* **1.** 1) Кара төсле

2) *күч.* Бәхетсез, күңелсез, тискәре. *Нә сәбәбтән килде безгә буйлә бер бәхте сияһ.* Г.Тукай

**2.** *и. мәгъ.* Кара, язу карасы

**СКА́ЛЬПЕЛЬ** *и. лат.* Кечкенә хирургия пычагы. *Мин исә хәзер, теләгән тәкъдирдә дә, кулыма скальпель ала алмаячакмын.* М.Хәсәнов. *Менә операциянең иң мөһим, җаваплы өлеше башланды: Изаил Харисович скальпель белән озын гына итеп сызып җибәрде.* М.Маликова

**СКАЛЯР** *и. мат.* Тик бер реаль сан белән генә характерлана торган, юнәлешкә бәйләнмәгән зурлык. *Скалярга мисал итеп мәйдан, вакыт, озынлык, масса, тыгызлык, температура, агым һ.б.ш.ны китерергә була*

**СКАНДАЛ** *и. фр.* Гауга, җәнҗал, ызгыш-талаш. *[Белевич:] «Син бу скандалның төп сәбәбен яхшы аңлый торгансыңдыр бит?» – дип сорады.* Ш.Усманов

**СКАНДАЛИСТ** *и. рус* Җәнҗал чыгаручы, гаугачы, тавыш куптарырга яратучы

**СКА́НЕР** *и. ингл.* Нинди дә булса сурәтнең яки текстның сурәтен цифрлы форматка күчерә торган техник җайланма. *Мин аны сканер аша үткәреп, компьютер хәтеренә керттем һәм сугышка китәр алдыннан фотоплёнкага сеңеп кала алган авылдашларымның варисларына өләштем.* Р.Зарипов

**СКА́НЕРЛАУ** *ф.* Сканер ярдәмендә электрон күчермә алу. *Сәркатипне чакырып алып, бу мәкаләләрне сканерларга кушты.* Н.Көбәш

**СКАРЛАТИ́НА** *и. ит.* Тәнгә вак тимгелләр чыгу, тамак авырту, температура күтәрелү белән үтә торган йогышлы балалар авыруы. *Былтыр Куштирәктә скарлатина инфекциясе таралган булган икән.* Н.Фәттах. *Бу инде мәхәббәт түгел, чир дигән сүз. Кырыкка җиткәч скарлатина белән авырган кебек, кешенең көчен-егәрен ала.* М.Маликова

**СКАФА́НДР** *и. гр.* 1) Су астына төшү өчен, су үткәрми торган резинлы тукымадан эшләнгән, күзлекле металл шлемы булган махсус герметик кием. *Офицерлар скафандр кебек киемнәрдән траншеядагы приборлар янына бастылар.* Х.Камалов

2) Очучыларның яки космонавтларның сыек атмосфера яки космос шартларында эшләргә мөмкинлек бирә торган, сулау өчен герметик шлемы булган махсус герметик костюмы. *Нишләп соң әле, мин әйтәм, татарлар арасында бер генә космонавт та юк? Нужәли инде арабыздан скафандр кидерерлек бер кеше табылмас икән?* К.Кәримов

**СКВА́ЖИНА** *и. рус* 1) Берәр нәрсәдә тар тишек, уем

2) Су, нефть һ.б.ш. берәр казылма чыгару өчен, җирне бораулап ясалган тирән тар тишек; тишем. *Скважинадан кара алтын бәрә башлады.* М.Хәсәнов. *Аларны бер хуҗа үз җирендә скважина бораууларга яллаган.* Х.Камалов

3) Шундый казылмалар чыгарылу урыны һәм шуны тәэмин иткән техник корылмалар. *Яшеллеккә төренә башлаган тал әрәмәлекләре арасында, күзнең явын алып, скважиналарның көмеш җиһазлары елык-елык ялтырый.* Ә.Касыймов. *Әмма Гази белә: ажаган түгел бу. Кама буендагы нефть скважиналарының берәрсе янында факел янадыр.* М.Хәсәнов

**СКВЕР** *и. ингл.* Агач, куак, чәчәк кебек үсемлекләр утыртылган кечкенә бакча. *Әнә тегендәрәк сквер. Ире, хатыны, дүрт-биш баласы җәйма җәйгәннәр дә тәгәрәшеп йоклыйлар.* М.Мәһдиев. *Фәннан Барышев машинасын Фәүрияләр йорты башына китереп туктатканда, каршыдагы сквер буеннан такси кузгалып китте.* М.Хуҗин

**СКЕЙТ** *и. ингл. сөйл. к.* **скейтборд**. *Операция белән бармакларын аергач, ул компьютерда язарга, скейтта йөрергә өйрәнә.* Безнең гәҗит

**СКЕЙТБОРД** *и. ингл.* Скейтбординг белән шөгыльләнү өчен кечкенә тәгәрмәчләр беркетелгән такта; роликлы такта. *Шуннан аллея кырыена куелган эскәмияләргә утырып, роликлы тимераякта шуучыларны, велосипед, скейтбордта йөрүчеләрне күзәттек.* Сөембикә

**СКЕЙТБО́РДИНГ** *и. ингл.* Скейтбордта йөрүдән, шуның белән төрле трюклар ясаудан гыйбарәт экстремаль спорт төре. *21 июньдә дөньяда скейтбординг көне билгеләнә.* Кызыл таң

**СКЕЙТБОРДЧЫ** *и.* Скейтбординг белән шөгыльләнүче кеше. *Архитектор планында фонтан, төрле чаралар үткәрү өчен трибуна белән сәхнә урнаштыру, скейтбордчылар өчен мәйданчык, шахмат уйнау өчен өстәлләр, --- тузеклэндерелгән чишмә дә бар.* Хезмәт даны

**СКЕ́ЙТЧЫ** *и. сөйл. к.* **скейтбордчы**. *Казанның скейтчылары белән BMX-райдерлары быелгы сезонны тәмамлады.* Шәһри Казан

**СКЕЛЕТ** *и. гр.* Кеше һәм хайван организмында терәк һәм механик зарарланулардан саклау функцияләрен

үти торган каты тукымалар; сөлтәр. *Һай бу ачлыкның күңелсезлеге! Рәссамнар скелет рәвешендә итеп бик дөрес сурәтлиләр аны.* М.Мәһдиев. *Олы кеше скелеты үзара тоташып урнашкан 220 ләп сөяктән гыйбарәт.* Биология

**СКЕ́ПТИК** I *и. гр.* 1) *филос.* Скептицизм тарафдары

2) Нәрсәгә дә булса ышанмыйча, шикләнеп караучы кеше. *Скептиклар да кирәк. Алар кайчак катализатор вазифасын үти.* Г.Хөсәенов

**СКЕ́ПТИК** II *с.* **1.** 1) Ышанмаучан, тәнкыйтьчән, икеләнүчән (кеше, холык тур.). *Әйткәнемчә, һәрчак шат кеше була, скептик затлар да була.* Х.Камалов

2) Ышанып җитмәүне белдергән, икеләнү сизелгән (караш, үз-үзен тотыш). *Фән фараздан, идеядән башлана, беләсең килсә... Моңа мин скептик караштa...* Г.Хөсәенов. *Күп кенә морзаларның, зыялыларның төп кавемнән аерылып каста кебек яшәве, урыс тормышын кыйбла итүе, үз милләтенә скептик мөнәсәбәте гавамның аерым вәкилләрендә кызыксыну, алар кебек булырга омтылу теләген дә тудырды.* Х.Миңнегулов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ышанычсыз, ышанмыйча, икеләнү яки тәнкыйть белән. *Ә Гайнанов?.. Ул да безгә скептик карый... Кемне тәкъдим итәсез соң?..* Х.Камалов. *Иҗат оешмалары хакында нинди генә фикерләр (иҗатчыларның үзләре арасында да андый берлекләргә скептик караучылар бар) булмасын, реаль фактны танымый мөмкин түгел ---.* Р.Фәйзуллин

**СКЕ́ПТИКЛЫК** *и.* Скептикка хас сыйфатлар; ышанмаучылык, шикләнүчәнлек. *Аның [Й.Акчураның] скептиклыгы түгел, самимилек белән сугарылган «бәхетсезлеге» турындагы үртәнүле сүзләре игътибар үзәгенә куелырга тиеш.* М.Гайнетдинов

**СКЕПТИЦИЗМ** *и. гр.* 1) *филос.* Объектив чынбарлыкны дөрес итеп танып белү мөмкинлеген инкяр итә торган юнәлеш

2) *кит. к.* **скептиклык**. *Бу урында бөек драматург Бернард Шоу сүзләрен искә төшерәсе килә: гражданлык тәрбиясе властьларга сукырларча буйсынырга өйрәтү түгел, ул – кешедә килешмәүчәнлек, мөстәкыйль фикерләү, скептицизм, камиллеккә омтылыш һәм гамь тәрбияләү.* Ю.Сафиуллин

**СКЕ́РЦО** *и. ит. муз.* 1) Үтә кызу темплы, гадәттә шаян темалы кечерәк күләмле инструменталь әсәр. *Алар арасында җыр-романслар гына түгел, прелюдия, ноктюрн, интермеццо, скерцо, музыкаль мизгел, юморескалар һ.б. бар.* Мәдәни җомга

2) Симфония, соната һ.б.ш. кебек зур музыкаль әсәрләрнең шундый характердагы берәр кисәге

**СКЕТЧ** *и. ингл.* Кыска күләмле, гадәттә көнүзәк темаларга язылган юмористик пьеса. *Скетч Һ.Такташның соңрак чыккан әсәрләре җыентыкларына берничә мәртәбә урнаштырылган.* Р.Гаташ

**СКИПИДАР** *и. лат.* Ылыслы агачлар сумаласыннан куыла, медицинада һәм буяу җитештерүдә кулланыла торган зәһәр исле, саргылт төсле яки төссез сыекча. *Скипидар дару һәм лаклар җитештерүдә кулланыла. Скипидар исе*

**СКИФ** I *и.* Безнең эрага кадәр җиде гасыр элек безнең эрада өч гасыр Кавказ тауларының һәм Кара диңгезнең төньягындагы далаларда яшәгән борынгы кабиләләр берләшмәсенең атамасы һәм шуннан бер кеше. *Скиф һәм төркиләрнең дини-мифологик билгеләре буенча да нигездә бер үк халык булулары күзәтелә.* М.Зәкиев. *Боларның [тарихчыларның] сүзләре дөрес булса да, дөрес булмаса да, язма тарих барлыкка килгән вакытларда бу урыннарда скиф, сармат кавемнәренең торулары мәгълүмдер.* Мирас

**СКИФ** II *и. ингл. спорт* Академик ишүдә озын, тар ярыш көймәсе; шундый көймәләр классы

**СКЛАД** *и. рус* Товарны кабул итү, урнаштыру һәм саклау, файдалануга һәм кулланучыларга җибәрү өчен билгеләнгән бина, корылма. *Урыс агай икмәк егылып уңа торган төбәкләргә икмәк складлары салган.* М.Мәһдиев. *«Райпотребсоюз» складына ике аяклы күсе оялаган», – дип, явыз кешеләр өстемнән яздылар.* М.Кәримов

**СКЛЕРОЗ** *и. гр. мед.* 1) Эчке әгъзаларда яки аерым тукымаларда берәр элемент җитмичә, аның тоташтыргыч тукыма белән алмаштырылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән тыгызлану, катырудан гыйбарәт авыру. *Ул гипертония миндә дә бар. Җитмәсә, склероз.* А.Расих. *Минем аяк чире тагын кузгалды (тромбофлебит). Ятам. Ул склероз белән бәйләнешле.* Г.Бәширов

2) *сөйл.* Онытучанлык. *Әһем, ә-ә, склероз дигән сүзнең үзен дә онытып яши бирәбез!* Ш.Галиев. *Иң элек бәйрәм белән котлап куйыйм, я каһәр төшкән склероз аркасында онытып җибәрермен.* Ф.Яруллин

**СКЛЕРОЗЛЫ** *с.* 1) Склероз белән зарарланган. *Склерозлы тамырлар*

2) Склероз белән авыручы. *Склерозлы авыруларның хәлен күзәтеп тору*

3) *сөйл.* Онытучан. *Кыскасы, юкка иләсләнмә, күңел, алда сине бернинди романтика да көтми, көтсә, тик авыл хәлләрен сорашырга җыенучы склерозлы карт көтә булыр.* Ф.Хөсни. *Игътибар итегез, шуны уйларга акылым җиткән, ә менә уянгач, күпме эзләп, күпме баш ватып та исемә төшерә алмаганмын, менә бит ул, кем әйтмешли, склерозлы баш!* Ә.Еники

**СКОЛИОЗ** *и. гр. мед.* Умыртка баганасының кәкрәюе. *Татарстанда һәр йөз баланың 80ендә сколиоз. Әлеге чирне тиз генә дәвалап булмый, дөрес яшәү генә коткара ала.* Л.Зәйнуллина. *Сәламәтлеге какшаган балалар да йөри. Алары күбрәк сколиоз авырулы.* А.Шәймәрданов

**СКОТЧ** *и. ингл.* Ябышкак тасма. *Скотч белән ябыштыру*

**СКРЕ́ПЕР** *и. ингл. махс.* Җир катламнарын чүмече белән казып алып, күчереп, икенче урынга өеп бара торган үзйөрешле яки тагылма машина. *Бу каналны скрепер дигән машина кыш көне казыган иде. Шул канал буенча суалгычка су килергә тиеш.* А.Алиш. *Яз җитү белән бульдозер яки скрепер кирәк булачак.* М.Шабай

**СКРЕ́ПЕРЧЫ** *и.* Скреперда эшләүче. *Теләнче Тамак урта мәктәбен тәмамлагач, Чаллының 8 нче урта һөнәри-техник училищесында укый:*

*автогрейдерчы, скреперчы, автослесарь, машина йөртүче, комбайнчы һөнәрләрен үзләштерә.* Якты юл

**СКРИ́ПКА** *и. рус* Сызгыч (кәманча) белән уйнала торган дүрт кыллы, иң югары регистрлы музыка уен коралы. *Имештер, мин скрипкада ниндидер бер --- үтә нечкә, шундый гаять тә нәфис бер көй уйныйм.* Г.Бәширов. *[Исмәгыйль:] Энем Исхак белән без халык алдына скрипка, мандолина уйнарга чыккан чакта, әле безгә ун яшьтән артык түгел иде.* Г.Ахунов

**СКРИ́ПКАЧЫ** *и.* Скрипкада уйнаучы музыкант. *Пианино почмагында чәүкә төсле кара фраклы скрипкачылар бу залга әкият сарае төсен бирәләр.* К.Нәҗми. *Атларның кайберләрендә артка карап утырган курайчылар һәм скрипкачылар да бар иде.* М.Гали

**СКУ́ЛЬПТОР** *и. лат.* Скульптура әсәрләре иҗат итүче сәнгатьче, сынчы. *Скульптор да, рәссам да кеше анатомиясен шәп белергә тиеш.* Ш.Галиев. *Алдагы хатымда скульптор Роденны искә алсам, ә хәзер архитектор Монферран «миемне бораулый».* Н.Нәҗми

**СКУ́ЛЬПТОРЛЫК** *и.* Скульптор һөнәре, сынчы осталыгы

**СКУЛЬПТУ́РА** *и. лат.* 1) Чоку, кисү, эвәләү яки кою юлы белән күләмле сурәтләр (статуя, бюст, барельеф һ.б.) тудыра торган сәнгать төре. *Бу залларда скульптура, рәсем сәнгатенең дөньякүләм әһәмиятле әсәрләре куелган.* М.Мәһдиев

2) Шундый сәнгать әсәре, сын. *Бакчаның уртасында мәрмәр бала скульптурасы курай аркылы югарыга су пошкыртып тора.* Ш.Камал. *Юллар чатында ялгыз кабер. Өстендәге агач корыган, кайрысы кубып, шыр сөяккә калган, әйләнеп узганда, скульптура сыман күренә.* Ш.Галиев

**СКУ́МБРИЯ** *и. гр.* Алабугасыманнар отрядыннан орчыксыман гәүдәле, әһәмиятле промысел объекты булган диңгез балыгы. *Акула, белуга, скумбрия, медуза каптырып биримме?* И.Юзеев. *Скумбрияләр өерләре белән йөзәләр.* Зоология

**СЛАВИСТ** *и. рус* Славистика белгече

**СЛАВИ́СТИКА** *и. рус* Славян телләрен, әдәбиятын, культурасын, тарихын, көнкүрешен һ.б. өйрәнә торган фәннәр җыелмасы

**СЛАВЯН** *и. рус* Һинд-европа телләре семьясына кергән, шул исемдәге төркем барлыкка китергән, уртак культурага ия булган, Европа һәм Азиядә яши торган халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Төрки булган болгарларның бер өлеше кайчандыр Дунай яры буена барып урнашкан һәм славян культурасын үзләштергән.* Т.Миңнуллин. *Алтын Урда чорында Идел буе болгарлары һәм угро-фин этник төркемнәренә көнчыгыш славян халкы да үтеп керә.* Б.Хәмидуллин

**СЛАВЯНЛАШУ** *ф.* Тел һәм культура ягыннан славянга әйләнү, славян тәэсиренә бирелү. *Шул ук вакытта Дунай буенда да Болгар дәүләте барлыкка килә. Бу дәүләт башта йөз ел чамасы төрки була, соңыннан славянлаша.* Н.Фәттах

**Славянлаша бару** Вакыт узган саен ныграк славянлашу

**Славянлаша башлау** Славянлашуга йөз тоту

**Славянлашып бетү** Бөтенләй славянлашу

**СЛА́ЛОМ** *и. норв. спорт* 1) Бормалы трасса буйлап таудан төшүдән гыйбарәт чаңгы спортының бер төре. *Монда иелә-бөгелә слалом да шуалар, трамплиннан да сикерәләр һәм арты киселгән бер генә чаңгыда шундый әкәмәтләр ясыйлар – карап туймассың!* Ә.Мушинский

2) Тау елгаларыннан байдаркалар белән төшү ярышы. *Су слаломы*

**СЛАЛОМЧЫ** *и. спорт* Слалом белән шөгыльләнүче

**СЛА́НЕЦ** *и. гр. геол.* Токым ясаучы минералларның паралель урнашуы белән характерлана торган һәм юка пластинкаларга аерылучан вак бөртекле тау токымы. *Бу уйлап табуларның кайберләре --- Эстониядәге сланецлар комбинаты кебек предприятиеләргә дә экономия ясарга мөмкинлекләр тудырды.* Э.Касыймов. *Моннан кала, Татарстан республикасында нефть битумы, күрән ташкүмер, яна торган сланец, цеолит, бакыр, боксит ятмалары бар.* Табигый байлыклар

**СЛЕ́САРЬ** *и. нем.* Металл әйберләрне кулдан эшләү, җыю һәм төзәтү остасы. *Заводка мине өйрәнчек слесарь итеп эшкә алдылар.* Х.Туфан. *Институтта биш ел буе бию түгәрәгенә йөргән егет заводта да токарь, слесарь яшьләрне җыеп биергә өйрәтә.* Р.Корбан

**СЛЕ́САРЬЛЫК** *и.* Слесарь һөнәре, вазифасы һәм хезмәте. *Слесарьлык эшен мин үзем торган шәһәрдә, Смирнов исемле кустарь хуҗа кул астында өйрәндем.* Ш.Усманов. *Барометр, термометр кебек приборлар, слесарьлык, столярлык станоклары бар.* Т.Гыйззәт

**СЛЁТ** *и. рус* Берәр оешма әгъзаларының, уртак һөнәр ияләренең зур җыелышы. *[Вәзир:] Айдар кыш буе класста староста булды, Габдулла стена газетасына сайланды, район слётына барды.* М.Кәрим. *Алтынчы ел бер администрация бинасын да төзеп чыга алмаганны. Җимерек клубта слёт уздырабыз. Булган автовокзалны да сүтеп аттылар.* Н.Хәсәнов

**СЛИ́ВА** *и. слав.* 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан башлыча төньяк ярымшарның уртача климатында үсә торган җимеш агачы яки куагы. *Еракта ташландык чия, алма, кура җиләге, слива бакчалары күренә.* Т.Галиуллин. *Төрле-төрле сорт алмагач, слива, груша, чия, кызыл карлыган, кура җиләге дисеңме – барысы да бар.* Ә.Һидиятов

2) Шул агачның аксыл шәмәхә, каралҗым яки ачык сары төсле сусыл җимеше. *Аның пешкән слива кебек күзләре очкынланып китте.* Г.Әпсәләмов. *Без, аны кызганып, һәр көн өебездән нәрсә дә булса алып килә идек: я алма, я слива, я кипкән балык.* М.Мәһдиев

**СЛОВАК** *и.* Көнбатыш славян төркеменә караган, күпчелеге Словакиядә яшәүче, католик динен тоткан халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Оленька словак һәм украин балаларын даими рәвештә Киев, Братислава һәм Парижга сәяхәткә йөртә икән.* А.Хәлим. *Шул кемдер бәхәсле дип санаган «Намус» романы инглиз, француз, испан, болгар, венгр, поляк, чех, словак,*

*кытай, немец, албан телләренә тәрҗемә ителгән.* Ә.Рәшит

**СЛОВЕН** *и.* Көньяк славян төркеменә караган, күпчелеге Словениядә яши, католик динен тота торган халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Ирланд, фин, словен, поляк, итальян, испан, португал, дат телләреннән беренче дәресләрне нәкъ монда алырга мөмкинлек туды.* А.Миңневәлиева

**СЛЮДА** *и. рус* Үтәкүренмәле, катламлы табигый минерал; пыялаташ. *Себер тауларында пыяласыман үтәкүренмәле мәгъдәннәр – слюдалар бар икән. Шулар кояшта алтынсыман булып ялтырыйлар икән.* Г.Әпсәләмов. *Слюда магматик һәм утырма тау токымнарын оештыруда катнаша.* Төзү минераллары

**СМАРТ** *и. ингл.* Кушма сүзләрдә «компьютер үзлекләренә ия, акыллы» мәгънәсендәге беренче компонент

**СМАРТ КА́РТА** *и. ингл.* Микропроцессоры һәм хәтерләү җайланмасы булган пластик банк картасы

**СМАРТФОН** *и. ингл.* Кечкенә персональ компьютер мөмкинлекләрен үз эченә алган мобиль телефон. *Җитмәсә, түшенә зур шоколад хәтле смартфон дигән нәрсәкәй асып куйган.* Ф.Баттал. *Смартфон – кесә компьютерын һәм телефонны үз эченә алган җиһаз.* А.Әпсәләмова

**СМЕ́НА** *и. рус* 1) Эшләүчеләр, ял итүчеләр, укучылар һ.б.ш.ның бер төркемен икенчесе алмаштырганчы дәвам иткән вакыт арасы. *Сәрвәр әвендә төнге сменага ашлык сугуда кала.* Р.Төхфәтуллин. *Смена тәмамланганчы, зонадан чыкмадык.* А.Гыйләҗев

2) Шушы вакыттагы эш, хезмәт, ял һ.б.ш. *[Һарунның] Инженер улы шәһәр якынындагы ял йортына путёвка әзерләп куйган иде. Бер генә сменага да түгел, берьюлы ике сменага!* Ф.Хөсни. --- *Кешеләр үз сменалары өчен генә түгел, бәлки бүтәннәр сменасы өчен дә үзләрен җаваплы итеп сизделәр.* Н.Фәттах

3) *җый.* Бер сменада (*1 мәгъ.*) эшләүчеләр, укучылар һ.б.ш. төркеме. *Ял итүче смена йокыга да китте, без йокламаска тиешле смена егетләре белән үзара озак сөйләшәбез.* А.Расих. *Беренче смена, ашыга-ашыга, өенә йөгерде. Ун минут үткәч, икенче смена дәрес башлады.* М.Мәһдиев

**СМЕ́НАДАШ** *и.* Бер үк сменада эшләүчеләрнең берсе. – *Әни бу минем... Комиссия! – дип күз кысты Зөлфә лабораториядә эшләүче сменадашы Раяга.* Э.Касыймов

**СМЕ́НАЛАП** *рәв.* Сменаларга (*1 мәгъ.*) бүлеп яки бүленеп, алмашлап, чиратлашып. *Гаҗәп инде, элек заводта гына сменалап эшлиләр иде.* Т.Гыйззәт. *Аннары, тәрбиячеләр сменалап эшләгәнлектән, балалар әле бер, әле икенче тәрбиячегә ияләшергә тиеш була.* Ф.Яруллин

**СМЕ́НАЛЫ** *с.* Сменалап оештырылган; сменаларга (*1 мәгъ.*) бүленгән. *Мин Лена, Дзидралар белән кызып-кызып язышкан арада, заводны ике сменалы эшкә күчерделәр.* А.Гыйләҗев. *[Хатын:] Сменалы эштә: бер тәүлек эшлим, ике тәүлеккә якын өйдә.* Казан утлары

**СМЕ́НАЛЫК** *с.* Билгеле бер сменага җитәрлек, шуңа исәпләнгән. *«Әгәр теләсәң, тагын бер сменалык путёвка алып бирергә можем», – дигән мәгънәне ишеткән кебек була – бар, каршы сүз әйтеп кара әнә шундый нәзакәтле балаларыңа.* Ф.Хөсни

**СМЕ́ТА** *и. рус* Булачак керемнәрне һәм чыгымнарны чамалап, алдан ясалган исәп; берәр эшханәнең, оешманың шундый исәп язылган документы, финанс планы. *Казанда чакта онытылып торган баш врач эшләре: дебет-кредит, смета һәм түләү ведомосте, утын, аш-су, кер юу, ремонт хәстәрләре кебек нәрсәләр яңадан аның башына тулды.* Г.Әпсәләмов. *Вафат булган язучы гаиләсенә ярдәм итү өчен дә шул ук нисбәттә акча бирелә иде. Смета төзегәндә, ел саен ул исемлекләр Мәскәүгә җибәрелеп торды.* Л.Хәмидуллин

**СМИ́РНО** *ы. рус хәрби* **1.** Сафта төз басып хәрәкәтсез торырга кушкан хәрби боерык. *Солдат «Смирно!» командасы биреп, картны туры катырып бастырырга да уйлап куйган иде, тик тыелып калды.* М.Кәрим. *Мин шулай уйланып торганда, команда булды: «Смирно!» Бөтен строй аз гына селкенеп алды да бик тиз тынып калды.* Г.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Төз һәм хәрәкәтсез. *Хәзер, смирно басып, сугышчан боерык көтеп торганда, өлкән сержант тагын бер тапкыр шул турыда уйлап алды.* Г.Әпсәләмов. *Туктыйсыңмы, юкмы, эт җыккыры! Ату шушы егетләр алдында смирно бастырам бит үзеңне!* Ә.Еники

**СМОТР** *и. рус* 1) *хәрби* Гаскәрне тантаналы төстә рәсми тикшерү, карап чыгу. *Мин үз күзем белән күреп чыгар өчен, легионны смотрга хәзерләргә куштым.* Ш.Усманов. *Радио сөйли: «Көләч йөзле, шат күңелле корыч колонналар Кызыл мәйдан аша агылалар. Бүген совет халкы үзенең сугышчан көчләренә смотр ясый».* А.Алиш

2) Берәр төрле эшчәнлек нәтиҗәләрен халык алдында күрсәтү, халык тарафыннан тикшерү. *Шунда укучылар ясаган иң яхшы модельләр смотр өчен сайлап алыначак.* Г.Рәхим. *Операның премьерасы бер ай эчендә әзерләнеп бетә: аны Россия Федерациясенең милли театрлары смотрына өлгертәләр.* Мирас

**СМУ́ЗИ** *и. ингл.* Блендер ярдәмендә тугланган төрле җиләк-җимеш яки яшелчәгә сөт, сироп яки җимеш суы кушып әзерләнә торган татлы куе эчемлек. *Алма белән кыяр смузие*

**СНА́ЙПЕР** *и. ингл.* 1) Махсус әзерлекле төз ату остасы; мәргән. *Тынлыкны бердәнбер ату тавышы боза: фашист снайперының чиркәү түбәсеннән аткан пулясы майорның гомерен өзә.* Г.Ахунов. *Шулай итеп, гомер бакый күзлек кимәгән, кичен китапны ут яндырмый да укый алган Габделкадирны снайперлар исемлегенә беренче итеп яздылар.* Идел

2) Спорт уеннарында каршы команданың капкасына, кәрзиненә гол кертүче, командада шундый бурыч куелган уенчы. *Дөрес, Татарстан башкаласына былтыр Рига «Динамо»сы өчен уйнаган һәм КХЛның иң яхшы снайперы булып танылган Марцел Хоссаның кучү мөмкинлеге турында мәгълүматлар бар.* Ватаным Татарстан

3) Ялланган үтерүче, киллер. *Снайпер җибәрмәгәйләре.* З.Хәким

4) *күч.* Бәреп, ыргытып, очыртып һ.б.ш. юл белән берәр нәрсәгә оста тидерүче. *Еланнарның барысы да түгел, Африка кобрасының ике төре һәм Һиндстан кобрасы – бик шәп снайперлар.* Кызыл таң

**СНА́ЙПЕРЛАРЧА** *рәв.* Снайпер кебек, снайперлар осталыгы белән. *Снайперларча ату*

**СНА́ЙПЕРЛЫК** *и.* 1) Снайпер һөнәре һәм сәләте; төз ату осталыгы. *Снайперлыкка өйрәнүләр үткәннән соң, унтугыз яшьлек егет тә Чечняга озатыла.* Шәһри Казан

2) *күч.* Снайперлар кебек үткен күзле булу, бәреп берәр нәрсәгә тидерү һ.б.ш.ны булдыру үзлеге. --- *акбур кисәген чиртеп очырган төсле генә итеп атып җибәрә тегенең маңгаена. Арттарак утырганы булса да, тидермичә калмый. Соклана идек аның снайперлыгына.* Ф.Сафиуллин

**СНАРЯД** *и. рус махс.* 1) Туптан ату өчен, эченә шартлаткыч куеп эшләнгән хәрби припас төре; ядрә. *Сызгырып очкан снарядлар, туктаусыз тыкылдаган пулемётлар төннең тынлыгын боздылар.* А.Расих. *Шул мәлне 1941 елның ноябрендә Мәскәү янында аның сул иңбашына кереп утырган снаряд ярчыгы кузгалып куйды.* М.Кәрим

2) *спорт* Гимнастик күнегүләр ясау өчен хезмәт иткән әсбап яки җайланма

3) *тех.* Билгеле эшләр башкару өчен хезмәт иткән механизм, аппарат

**СНОУДБОРД** *и. ингл.* 1) Карлы тау битләреннән яки махсус ясалган калкулыклардан шуу өчен җайлаштырылган махсус тактадан гыйбарәт спорт снаряды. *Мин Кандракүл буендагы тауда кинәнеп сноубордта шуам, үземә яңа көч-куәт алам.* Кызыл таң

2) *к.* **сноубординг**. *Иң күп медальләр тимераякта һәм чаңгыда узышу, биатлон, таудан чаңгыда шуу, сноуборд һәм фристайл төрләрендә җиңүчеләргә биреләчәк.* Татарстан яшьләре

**СНОУДБО́РДИНГ** *и. ингл.* Сноубордта карлы тау битләреннән зур тизлек белән шуып төшүдән гыйбарәт спорт төре. *Иң көчлеләрне биатлон, чаңгы, тимераякта узышу, фристайл һәм сноубординг ярышларында ачыклаячаклар.* Ватаным Татарстан

**СНОУДБОРДЧЫ** *и.* Сноубординг белән шөгыльләнүче кеше. *31 мартта «Казан» милли мәдәни үзәге каршында сноубордчыларның сезоны ябылу тантанасы була.* Шәһри Казан

**СОБОР** *и. рус* 1) *тар.* Элекке Россиядә дәүләткүләм оештыру-идарә мәсьәләләрен карап хәл итү өчен чакырыла торган түрәләр яки вәкилләр җыелышы. *Әйтеп үтелгән ике собор арасында төзелгән Никон елъязмасында еретикларга каршы тәнкыйть бик күп урнаштырылган.* Б.Хәмидуллин

2) Югары христиан руханилары җыелышы, съезды. *Уналтынчы йөз урталарында соборга җыелган архиерейлар, «сергачларның бозык гадәтләреннән [аю биетеп йөрүләреннән]» зарланып, патшага хат та язганнар.* К.Нәҗми

3) Шәһәрнең яки монастырьның иң зур чиркәве. *Яңа салынып ята торган соборга бераз гына иганә кертсәң, ул синең малайны гаскәрдән азат итү генә түгел, синең исемне изгеләр санына кертеп, чиркәүдә дога кылдырыр.* Ә.Фәйзи. *Собор тыкрыгында кайдандыр кайтып килүче Саескан Хөснулланы очратты.* К.Нәҗми

**СОВ-** *рус* Кыскартылган кушма сүзләрдә «совет» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *совхоз, совинформбюро, совнархоз, совнарком*)

**СОВЕТ** *и. рус* 1) Хакимиятне гамәлгә ашыра торган сайлаулы, вәкиллекле орган; шура; дәүләтнең иң югары хакимият органы; шундый идарә формасы; шундый хакимият. *Власть, ягъни хакимият, эшче-солдат һәм крестьян депутатларының Казан советына күчте.* Р.Мөхәммәдиев. *Татарстан Республикасының Дәүләт Советы*

2) Шундый идарә формасы булган Советлар Союзы дәүләте. *Базар мәйданын тутырган шәһәрнең иске буржуазиясе, хәзерге спекулянтлар, төркем-төркем булып, большевикларны, Советны сүгәләр.* К.Тинчурин. *Империалистлар, Совет властен бәреп төшерү өчен, әллә ничә мәртәбәләр корал көче кулландылар.* Г.Әпсәләмов

3) Төрле коллегиаль органнарның, үзәкләрнең исеме. *Институтның гыйльми советы. Диссертацияләр яклау советы*

**СОВЕТЛАШТЫРУ** *ф. тар.* 1917 елгы революциядән соң илдә Совет (*2 мәгъ.*) хакимияте урнаштыру, шундый органнар булдыру; шуның идеологиясен урнаштыру. *Мин әле Ленинградта учредилканы ташлап, киң массаны советлаштыру юлында матбугат аша каләм сугышы алып бардым.* Г.Ибраһимов. *Илне советлаштыру чоры*

**СОВЕТЛАШУ** *ф. тар.* Совет (*2 мәгъ.*) яклы булып китү, совет ягына чыгу; шуның идеологиясен кабул итү

**СОВЕТЧЫ** *и. тар.* Совет (*2 мәгъ.*) яклы кеше. *Шул ук мулла сөйләгәнчә, Муса соңгы көннәренә кадәр төшенкелеккә бирелмәгән, азат булачагына ышанычын югалтмаган, «чын советчы булып дөньядан киткән булырга кирәк».* Р.Мостафин

**СОВЕТЧЫЛ** *с.* 1) Совет (*2 мәгъ.*) яклы. *Совет балалар әдәбияты үзенә советчыл катлау язучылар кадрын тартты.* Ф.Кәрим. *Ләкин бит алар бүген контрреволюционерлар булсалар, иртәгә аларның чын күңелдән советчыл булулары да мөмкин ---.* К.Тинчурин

2) Шуның идеологиясе белән сугарылган. *Советчыл татар әдәбиятында исә активлыкның җирлеген күмәклек (коллективчылык), социалистик җәмгыять мәнфәгатьләре тудыра.* А.Әхмәдуллин. *Генетиканың бөтен ачышларын кире кагып, советчыл, Мичурин-Лысенко биологиясе уйлап чыгаручылар, бөтен дөньяны ипи белән тәэмин итәрлек илне ачтан тилмертүчеләр дә шулар [кызыл профессура].* А.Тимергалин

**СОВЕТЧЫЛЫК** *и. тар.* Совет (*2 мәгъ.*) яклы булу, советчыл караш

**СОВХОЗ** *и. рус* Русча «советское хозяйство» тәгъбиренең кыскартмасы: авыл хуҗалыгында дәүләт предприятиесе. *Күрәсең, совхозны рәткә салмаган дип, Вәли байны яманларга да, гаепләргә дә урын һич юк.* Г.Нигъмәти. *Әти хәзер совхозның төзү бригадасында эшли.* Р.Төхфәтуллин

**СОВХОЗДАШ** *и.* Бер үк совхозда эшләүче кешеләрнең берсе

**СОВХОЗЛАШТЫРУ** *ф.* Совхоз итеп үзгәртеп кору

**СОВХОЗЛАШУ** *ф.* Совхоз булып оешу

**Совхозлаша башлау** Совхозлашырга тотыну

**Совхозлашып бетү** Барысы да совхозлашу

**СОВХОЗЧЫ** *и. сир.* Совхоз әгъзасы, совхозда эшләүче

**СОГЫНДЫРУ** *ф. йөкл. этн.* 1) Кунак итү йоласы буенча, итне кул белән алып, кунакның авызына каптыру. *Чәкәнләп сугылган зур чаршаудан корылган чатырларына чакырып, симезсимез калҗа согындырдылар, эчләре тулганчы кымыз эчерделәр.* М.Кәрим. *Теге дала күсесе Борындык сәет тә согындырырга оста, кулы килешеп тора... ул булмаса... урыслар сыйласын!* Р.Батулла. *Гарәп, ат итеннән бик чирканып кына, согындырган кисәкне бик түбәнчелек белән авызына капты.* Г.Гобәйдуллин

2) *сөйл.* Гомумән, бик нык кыстап, күп итеп ашату яки эчерү

3) Үч алу, ачу кайтару. *Бу муллага Җәләл күптән ачулы иде. Аны тыштан белдермәсә дә, голәма мәҗлесендәге бер сүзе өчен, аны кайчан да булса бер согындырырга уйлап йөри иде.* Г.Ибраһимов

**Согындыра башлау** Согындырырга тотыну. *Бай, табакны алдынарак тартып, кунак җегеткә сонды; Арысланбай, булдым, дигәч, хуҗа теге ишек төбендәгеләргә берәм-берәм согындыра башлады.* Г.Ибраһимов

**СОГЫНУ** *ф.* 1) Кул белән биргәнне кабу

2) Зур-зур кабып ашау. *Кулләрдә йөзеп йортка кайткач, --- ул бер вакытта да үз алдыннан ашамый, муены озынлыктан файдаланып, гел каршы яктан, туганнары алдыннан алып согына...* Н.Исәнбәт. *– Әйдә, утырышыгыз, җитешегез! Барыбер бөтенегезгә дә кашык чыкмас, кул белән генә согынызыз! – дип кыстарга кереште хуҗа.* М.Кәрим

**СО́ДА** *и. лат.* 1) Көнкүрештә һәм техникада кулланылган ак селтеле кристаллик матдә: натрий карбонатларының бер төре. *Кер содасы. Кальцийлы сода. Кристаллик сода. Каустик сода*

2) Медицинада һәм кулинариядә кулланыла торган углекислый натрий тозы; натрий карбонаты. *Чәй содасы*

**СОКЛАНГЫЧ** *с.* Соклandыра торган, сокланыр дәрәҗәдә яхшы, матур булган, соклану хисе уятырлык. *Синең дә, и татар, Сыйфатың, саның бар, Холкыңда, йолаңда Сокланrыч ягың бар.* Х.Туфан. *Сокланrыч та соң бу дөнья – Кояшы бар, ае бар.* М.Лерон

**СОКЛАНДЫРГЫЧ** *с. к.* **сокланrыч**. *--- Итил җир йөзендәге Фатих ибн Әхмәт белгән бер генә елгага да охшамаган иде. Анда Болгар ирләрендәге сыман сокландыргыч батырлык та, тиелгысыз кыргыйлык та, Болгар кызларындагы сыман күреп туймаслык күркәмлек тә, тыйнак юашлык та бар иде.* Н.Фәттах. *Партсъездлар тормышка ашмаслык программалар кабул итте. Һәм шулар һәммәсе дә кәгазьдә генә калды, ләкин алар сокландыргыч планнар иде!* М.Әхмәтҗанов

**СОКЛАНУ** *ф.* 1) Бик яхшы, матур нәрсәгә таң калып, яратып карау. *Егетләр берсен-берсе бүлдереп, сокланырга, телләренә салынырга тотындылар.* Г.Бәширов. *Олы инәемнең зирәклегенә менә әле хәзер килеп сокланам.* М.Кәрим. *Тукайның эсерларга соклануы, аларны югары куюы турыдантуры әйткән сүзләреннән дә күренә.* И.Нуруллин

2) *диал.* Кызыгу. *Кеше байлыгына соклану*

**Сокланып йөрү** Гел соклану. *Гамбәриянең кисәктән сорап куюы еллар буе бер-берсенә сокланып йөрүләрен беренче башлап ачыклаучы сүзләр иде бит.* К.Тимбикова. *Син, чыннан да, җырдагыча Гүзәл икән, Юрүзән. Син тагын да гүзәлләндең Мин сокланып йөрүдән.* Ә.Шәрипов

**Сокланып кую** Кинәт кенә соклану; бер тапкыр соклану. *Чегәннең куркынычлы юлдан искиткеч сизгер, төгәл баруына эчтән генә сокланып куям.* Р.Низамиев

**Сокланып тору** Күпмедер вакыт соклану; сөйләү моментында соклану. *Язгы саф матур гөлгә карап сокланган төсле генә, ул аңа карап сокланып торды.* К.Тинчурин. *Ә минем еракка китәсе юк, болай да барысын ерактан күреп, сокланып торам ---.* Н.Нәҗми

**Сокланып утыру** *сөйл. к.* **сокланып тору**. *Бу – шундый гаҗәп күренеш: читтән күзәткән кеше яшь хатынның бер елмаеп, бер җитди кыяфәткә керүен карап сокланып утырудан һич тә ялыкмас иде, мөгаен.* Д.Бүләков

**СОКЛАНУЛЫ** *с.* Соклануны белдергән, соклану катнаш булган. *Барысы да кызыксынып, нindидер сокланулы хөрмәт белән аларга карыйлар иде.* Г.Әпсәләмов. *Мәрьям --- тирә-якны балкытып һәм сокланулы карашлар белән тутырып, беркемгә дә исе китмәгән кыяфәт белән яр өстенә күтәрелер иде.* Г.Ахунов

**СОКМА** *и. диал.* Елга ярындагы биек урын

**СОЛ** *и. гар.* Берәр эшне эшләүдә күнекмә, эшнең рәтен белү, осталык, сәләт. *Күп эшләгән оста булмас, солын белгән оста булыр.* Мәкаль. *Көчтә түгел, солда.* Мәкаль. *Тора-бара ул [сукыр кеше] үзенең шомырт таягы ярдәмендә бик оста, бик җиңел йөри башлады. Анда эчке бер тойгы – сол барлыкка килде.* Ш.Еникеев

**СОЛБИ** *и. гар. иск.* Үз улы (үги түгел). *Һулагу Тули улы, Бәрәкә Җүҗи улы булып, Тули белән Җуҗи – Чыңгызның солби, ягъни үз улларыдыр.* Мирас

**СОЛБИЯ** *и гар. иск.* Үз кызы (үги түгел). *«Сез, кем, Садретдин Бәдретдин углы, үзеңнең солбия кызыңны, мәсәлән, Гайнетдин Зәйнетдин углына хатынлыкка вә җефетлеккә бирдеңме?»* Ф.Әмирхан

**СОЛДАТ** *и. нем.* 1) Армиядә, гадәттә коры җир гаскәрләрендә хезмәт итүче, хәрби дәрәҗәсе булмаган хәрби. *Трибунада өстенә озын шинель кигән яшь солдат күренде.* Ш.Усманов. *Шул вакыт әкрен генә тәрәзә чирткән тавыш ишетелде. Саҗидәгә өлкән апасы: – Бар! Солдатың килгән, ахры, – дип пышылдады.* М.Галәү

2) *сөйл.* Хәрби хезмәт. *Абзый, бу ел көзгә солдатка китеп калсам-нитсәм, акча кирәк булыр дип, тагын да эшкә*

*китте.* М.Гафури. *Менә аргы яктан, гармун тартып, быел солдатка алынасы никрутлар килеп төште.* Г.Бәширов. *Билен кысып буган, диләр, Бигрәк уңган, диләр; Әллә каян күренеп тора – Солдатта булган, диләр.* Ш.Маннапов

3) 1917 елга кадәр: солдат хезмәтендә булып кайткан кеше. *Мөхәммәтҗан җизни яшьрәк чагында озак кына солдат хезмәтендә йөреп кайткан. Шуңа күрә аны солдат Мөхәммәтҗан дип йөртәләр.* Г.Бәширов

4) *юг.* Гомерен берәр максатка багышлаган һәм шуңа тугры хезмәт иткән кеше. *Ул [Г.Бәширов] бит гомер буе солдат булып калган кеше. Партия солдаты булып. Әдәбият солдаты булып.* Р.Миңнуллин

**СОЛДА́ТКА** *и. рус сөйл.* Ире солдат хезмәтендәге хатын. *Кулы язу белгән кеше итеп, солдаткаларның күбесе, хат яздыру өчен, Гыйльменисага килеп егыла.* Ф.Хөсни. *Һай бу Шәяхмәт! Нинди сылу, яшь солдатканы эләктергән бит!* М.Мәһдиев

**СОЛДАФОН** *и. рус кимс.* Үз хезмәте белән генә чикләнгән тар карашлы, тупас кеше (гадәттә хәрбиләр тур.). *Военругыбыз җиңелчә яраланып кайткан бер солдафон иде.* К.Миңлебаев. *О-о, үз дәрәҗәсен бик белә иде, каршында фәннең «ф» хәрефен дә аңламаган солдафон утырганын аңлый иде ул.* М.Маликова

**СОЛИДАР** *с.* Берәү белән фикердәш булган, теләктәшлек иткән, солидарлык күрсәткән. *Солидар җаваплылык хисе*

**СОЛИДАРЛАШУ** *ф.* Солидарлык күрсәтеп берләшү; солидар булу

**СОЛИДАРЛЫК** *и.* Теләктәшлек, фикердәшлек, берлек; уртак фикердә булу. *Бармен --- малайны каты әрләде булса кирәк. Аның янына, йөгерешеп, иптәшләре җыелды. --- Бу үзенә күрә бәләкәй пролетарийларның солидарлыгы иде.* М.Мәһдиев

**СОЛИДОЛ** *и. лат.* Техник майлау материалы буларак файдаланыла торган куе майлы матдә; тавот. *Шыгырдавыклы яссы иләннәр. Бөтен җирдә автол, солидол, керосин исе килә.* М.Мәһдиев. *Каршыда таныш вагоннар, чатырлар калкып чыкты, мотоцикл фарасы ярып үткән якты ачыклыкта таныш нәрсәләр: ниндидер тимертомырлар, солидол мичкәсе һәм ике метр озынлыгындагы юан-юан агачлар күренеп калды.* Н.Фәттах

**СОЛИСТ** *и. ит. махс.* Үзе генә чыгыш ясаучы яки төп партияне башкаручы (җырчы, биюче, уен коралында уйнаучы һ.б.ш.). *Консерваториядә театр студиясе бетерелгәннән соң, татар өчен солистлар хәзерләү эше өзелде диярлек.* М.Җәлил. *Дөресен генә әйткәндә, заманында [Т.Якупов] җыр һәм бию ансамбленнән аерылып китмичә, һаман шунда күренекле солист булып җырлап йөргән булса, язмышы өчен отышлырак булыр иде, дип тә уйлыйм.* Л.Шагыйрьҗан

**СОЛИТЕР** *и. фр.* Пасьянс төре. *Әйтик, күбебезнең компьютерында солитер кебек карта уеннары бар.* Безнең гәҗит

**СОЛИТЁР** *и. фр.* Тасма суалчан

**СОЛЛЫ** *с.* **1.** Оста, маһир, булдыклы, уңган, кулыннан килә торган. *Соллы кеше май согынган, солсызның кулыннан төшкән.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Эшнең рәтен белеп, оста итеп, кирәгенчә. *Кулына ачкыч алып эшкә тотынгач, --- куллары да калтыранмады, киресенчә, соллы, төгәл хәрәкәтләнде, һәм шулай ук шешенке кыяфәте дә кисәк кенә үзгәреп киткәндәй булды.* Н.Фәттах

**СОЛСЫЗ** *с.* **1.** Теге яки бу эшкә күнекмәгән, осталыгы булмаган. *Гарәпша да --- чана артына үрмәләгән иде, ләкин солсыз кулда юньсез рәвештә әйләнеп торган чыбыркы очы аның колагын ныклап тешләп алгач, ул дача капкасы янында ук чанадан тәгәрәп төшеп калды.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Эшнең рәтен белмичә, рәтсез, уңайсыз, җайсыз (эшләү)

**3.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатка ия булган кеше. *Солсыз сапка сылтар.* Мәкаль

◊ **Солсыз сорнай** Сәләтсез, булдыксыз, мәнсез кеше. *Бак, шул солсыз сорнай да бездән уздымы?* Н.Исәнбәт. *Хет нәрсә дә булса эшләгәнсеңдер ич инде, солсыз сорнай?* З.Мәхмүди

**СОЛТАН** *и. гар.* 1) XI йөздән сәлҗүк төрекләрендә, XII йөзнең икенче яртысыннан Мисыр мәмлүкләрендә, гарәп илләрендә ил-дәүләт белән хакимлек итүче монарх, патша, хөкемдар. *Мисырда солтан бул, тик бездән ерак бул.* Мәкаль. *Солтан Мәхмүд Газнәвинең гадәтеннән: гаепле вә гөнаһлы кешегә исемен сорамаенча җәза бирмәс иде.* К.Насыйри. *[Гәрәй:] Син әйтеп бетермәдең. Анда [Төркиядә] солтан бар. Шул ук патша инде ул.* К.Нәҗми

2) XIV–XVII гасырларда Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында башлыча хан нәселеннән булган гаилә әгъзасының дәрәҗәсе, ханзадә. *Нургали хан зур байлык туплый алмаса да, ишле гаилә тота, кул астындагы солтан, старшиналары аңа табуннарын арттырырга ярдәм итәләр.* М.Галиев. *--- ханнарның сарай штатында нинди урыннар булганлыгын күз алдына китереп була. Алар, күрәсең, түбәндәгеләр булган: хан, ханча, ханзадәләр (ханәкә, кәнәкә, тәнәкә – хан кызы, солтан – хан углы яки кызы) ---.* Р.Әхмәтьянов. *Аның Мәскәү химаясенә баш органлыгын хатыны Фатыйма солтан өнәп бетерми.* Р.Батулла

3) Көнбатыш Африкадагы мөселман илләрендә эре феодал

4) Көньяк Гарәбстандагы кайбер кабиләләрдә кабилә башлыгы

5) Хатын-кызга хөрмәт итеп, яратып эндәшү яки аны атау сүзе. *Аһ, күзкәйләремнең яукайларын алырдай чибәр дә, сөйкемле дә зифа кыз Гөлсинәкәй солтан!* Р.Батулла

6) *куч.* Күп кеше арасында яхшысы, дәрәҗәлесе. *[Җиңги:] Мин йөрим инде, их, шушындый егет солтаны мине урласа, атамнан түгел, чуртыннан да курыкмас идем, дип.* Сөембикә

7) *куч.* Танылган һәм бердәнбер авторитет, хуҗа. *Инде әмриткән сүзең дә аяте Коръән түгел; Тәмле сүзең яки шелтәң күңлемә солтан түгел.* Г.Тукай

**СОЛТАНАТ** *и. гар.* **1.** 1) Солтан тарафыннан идарә ителгән дәүләт; солтан хакимияте. *Әгәр шаһиншаһ вафат булса, солтанат олы углына калсын.* К.Насыйри. *Аның максаты дала халыкларын бергә туплап Бөек Солтанат кору һәм шул Солтанатта тынычлык һәм гаделлек урнаштыру иде!* Р.Батулла

2) *куч.* Берәр төрле иҗтимагый күренешнең (мәс., илнең, җәмгыятьнең) көче. *Гыйлем вә мәдәнияттән милләткә күчеп йөргән кебек, сәяси куәт, ягъни солтанат – башка милләтләргә өстен булу вә хакимият тә – милләттән милләткә күчеп йөри, бер милләттә даими калмыйдыр.* Мирас

3) *куч.* Мәһабәтлек, мәгърурлык, дәрәҗәлелек (кыяфәт һ.б.ш. тур.)

**2.** *с. мәгъ.* Мәһабәт, мәгърур, дәрәҗәле. *Ишек ике якка ачылды. Зур буйлы, солтанат кыяфәтле, агара башлаган чәчле байбичә килеп керде.* Г.Ибраһимов. *Пантюркистларның максаты – хәзерге солтанат хәлифәтне төрки халыкларның уртак ватаны итеп танып, соңыннан аны Бөек Туран дәүләтенә әверелдерүдер.* М.Галәү. *Безне Бату хан чатырына алып бардылар. --- Бату хан гаять солтанат, ягъни бөек кыяфәттә тәхетендә утыра иде.* Мирас

**СОЛТАНАТЛЫ** *с.* 1) Зур дәрәҗәле, абруйлы; әһәмиятле, зур роль уйный торган. *--- безне үзенең солтанатлы хозурына чакырган падишаһе әгъзам хәзрәтләренең үтенечен кире кагарга җөрьәт итә алмыйм.* Ә.Еники. *Котбетдин әр-Рази, Сәгъдетдин Тафтазани, Хафиз ибне Баззази, Камалетдин Хуҗанди кебек үз чорының солтанатлы шәхесләре Сарайны фән һәм сүз сәнгате учагына әверелдерәләр ---.* М. Галиев

2) Мәһабәт, мәгърур, сокландыргыч. *Яраттым һәм солтанатлы күренешеңне, Яраттым мин матур, ыспай йөрешеңне.* К.Тинчурин

**СОЛТАНЛЫК** *и.* 1) Солтан исеме, солтан дәрәҗәсе. *Тогрыл 1055 елда Багдад шәһәрен яулап ала, һәм хәлифә аның солтанлык титулын таный.* М.Әхмәтҗанов

2) Солтанга буйсынулы хөкүмәт һәм дәүләт, солтанат (*1 мәгъ.*). *– Мин шушы Сәрандиб солтаны мәрхүм Мортаза шаһның улгымын, – диде. – Әтием вафат булганда, егерме бер яшьтә булып, солтанлык тәхетенә утырдым.* К.Насыйри

3) Солтан хакимияте; солтанның идарә итү чоры. *Мөхәммәд Рәшид Ризаның уйлавына караганда, хәзерге көндә ислам дөньясында хәлифәлек һәм солтанлык мәсьәләсе турысында өч төрле караш бар, имеш.* Г.Камал. *Сөләйман ханның солтанлык дәвере*

**СОЛТАНЛЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Солтан булып тору, хакимлек итү, ил белән идарә итү

2) *куч.* Хөкем сөрү, өстенлек итү. *Тормыш киңәйсен, һәркем иректә булсын, дөньяда матурлык белән ирек кенә солтанлык итсен.* Г.Ибраһимов

**СОЛЫ** *и.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан чәчәк һәм башаклары себеркәч хасил итә торган берьеллык үлән үсемлек – сабан ашлыгы. *– Атларың да бик өшәнгән, якындагы солыга гына барырга кирәк иде, – ди [әткәй].* Г.Ибраһимов. *Юлның ике ягында --- аксыл-яшькелт солы белән борай җире калды.* Г.Бәширов. *Равил, чыбыркысын сөйрәп, ашыга-ашыга, солы кибәннәре ягына йөгерде.* В.Нуруллин

2) Шул ашлыкның ярма ясауга, ат азыгы итеп кулланыла торган бөртеге. *Әле дә ярый атлар таза, аларның алдыннан солыны өзмибез.* Г.Ибраһимов. *Чепья базарыннан безнең авылга мари бәрәңгесе, удмурт-татар арышы, солысы кайтты.* М.Мәһдиев

◊ **Солы камыры** Йомшак холыклы, җебегән кеше

**СОЛЫБАШ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан чәчәкләре башакчыкларда, башакчыклар себеркәч чәчәк төркемендә булган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **овсяница**

**СОЛЫЛЫ** *с.* 1) Солы (*1 мәгъ.*) белән катнаштырып чәчелгән, арасында солы үскән. *Татарстан Республикасында силос өчен кукуруз, көнбагыш, солылы борчак, солылы вика катнашмалары үстерәләр.* Механизатор белешмәсе

2) Солысы (*2 мәгъ.*) булган, солы салынган, солы тутырылган. *Арбага түшәлгән печән астыннан солылы торыпшаны алып, элмәгеннән ат муенына кидерде.* М.Хәсәнов. *Әнә бер атның авызына солылы капчык бәйләгәннәр. Кештер-кештер килеп, ул шундагы солыны соса гына.* Р.Низамиев

3) Солы белән (*2 мәгъ.*) катышкан, аралашкан. *Ул тракторга тагылган вагонына солылы вика төяде.* А.Гыйләҗев

◊ **Солылы борай** *тар.* XVIII – XIX гасырларда көчләп чукындырылган һәм, чиркәү кенәгәсендә теркәлгәннән соң, кабат мөселманлыкка кайткан татар, элекке керәшен; мәкруһ. *Безнең авылда бер урам мөкрәһ (солылы борай) дигән халык бар иде.* Г.Чыгтай

**СОЛЫХ** *и. гар.* 1) Дәүләтләр, халыкларның үзара тату, сугышсыз яшәү хәле; тынычлык. *Хәзер сиңа сугыш түгел, солых кирәк.* А.Гыйләҗев. *Ленин: «Бетсен гадел булмаган сугыш! Халыкларга – солых, тынычлык, крестьяннарга – җир», – диде.* М.Әхмәтҗанов

2) Үзара сугышучы якларның сугышны туктату турында төзегән килешүе; пакт. *Явыз Иванның баскынчылык сәясәтен күреп һәм белеп торган Сөембикә хөкүмәте, солых килешүе төзү өчен, Мәскәүгә илчелек җибәреп карый.* Ф.Урманче. *Ниһаять, 1512 елның февраль аенда Казан белән Мәскәү дәүләтләре арасында гомерлек дип исәпләнгән солых килешүенә кул куелды.* М.Әмирханов

**СОЛЫХНАМӘ** *и. гар.-фар.* Солых турындагы килешү, шуның язуы. *Солыхнамә мирас алучылар арасында мал-мөлкәтне бүлешкәч тә төзелгән.* А.Тимергалин

**СОЛЫЧА** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан чәчүлекләрдә киң таралган солыга охшаш чүп үләне; кара солы, ач солы; *русчасы*: **овсюг**. *Вәзыйх арышның чокыр, кырын җирләрдә солыча баскан урыннарын сайлап чаптырды.* Х.Камалов. *Солычаның печәне яхшы терлек азыгы булып санала.* Ботаника

**СОЛЫЧЫК** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан себеркәч чәчәк төркемле, шуышма җир асты сабаклы терлек азыгы үләне; *русчасы:* **овсец**

**СОЛЬ** *и. ит. муз.* 1) «До» белән башланган музыкаль авазлар системасында бишенче тон. *--- яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль. Менә шулай! Ә авазлардан гамма хасил була, ди Салих.* Ә.Еники. *Музыкада да төп тавышлар җидәү: до, ре, ми, фа, соль, ля, си.* М.Мәһдиев

2) Музыка әлифбасында шушы авазны белдергән нота. *Хәзер менә*

*ноталарын гына искә төшерә дә. Соль, фа, соль, фа, ми, ми, ре.* Аманулла

**СОЛЯ́РИЙ** *и. лат.* 1) Кояш ваннасы алу өчен ачык һавадагы махсус мәйданчык. *Әнә сулдарак ак комлык, күрәсезме? Анда безнең солярий.* Г.Әпсәләмов

2) Ясалма кызыну өчен, махсус ультрашәмәхә лампалар белән җиһазландырылган аппарат. *Балигъ булмаган яшьтәгеләрнең һәр унынчысы солярий астында каралган тәнне матурлык дип саный икән.* Ватаным Татарстан

3) Шундый аппараты булган хезмәт күрсәтү учреждениесе һәм аның бинасы яки бүлмәсе. *Бу тәннең җәй көне – пляж, кыш көне солярий кебек нәрсәләрне күргәне бар микән?* Л.Әбүдәрова. *Бассейн, тренажёр заллары, массаж һәм косметика кабинетлары, солярий, чәчтараш, ресторан, сыра залы бар.* Татарстан яшьләре

**СОЛЯ́РКА** *и. рус* Дизель двигательләрендә ягулык буларак файдаланыла торган, нефтьне турыдан-туры куудан соң калган сыек матдә. *Иптәшләре тиз генә чүп-чар җыеп, солярка сибеп ут ягып җибәрделәр.* М.Хәсәнов. *Баш тракторчылар бәхәсләшә, ә ярдәмчеләре заправка белән йөгерешә, солярка, су ташыйлар иде.* Х.Камалов

**СОМГЫЛ** *с.* Нәзек озын, сыгылмалы. *Ул шушы ук талчыбыклар сыман сомгыл, нәзек, шома бармаклары белән санагыч таякчыкларын кат-кат сыйпады...* А.Хәлим. *Урман эченә төпкәрәк үткәч, малай сомгыл гына каенны кочаклады да нидер пышылдарга тотынды.* А.Баймөхәммәтов

**СОНА́ТА** *и. ит. муз.* Төрле темп һәм характердагы өч-дүрт өлештән торган инструменталь музыка жанры һәм шул жанрдагы әсәр. *Радио һәм телевидение тапшыруларында без аның фортепиано өчен язган сонаталарын, сюиталарын, прелюдия һәм концертларын ишетеп торабыз.* Г.Ахунов. --- *Теплоходларның ак салонында Бетховенның «Айлы соната»сы Агыла да һаман агыла.* Зөлфәт

**СОНАТИ́НА** *и. ит. муз.* Соната жанрына караган гадирәк музыкаль форма. *Ул берничә фуга, сонатина, концерт, квартет һәм, ниһаять, беренче симфониясен яза.* М.Җәлил. *«Флейта һәм фортепиано өчен сонатина», «Симфоник оркестр өчен сюита», «Симфоник оркестр һәм флейта өчен концерт» кебек күләмле әсәрләре бар.* Г.Мөхәммәтшин

**СОНГЫЙ** *с. гар.* 1) Табигый булмаган, чынга охшатып ясалган. *[Хатынның] Өске кат тешләреннән берсе куйган искусственный (сонгый) көмеш теш икәне, көлгән вакытта, читтән караган кешегә мәгълүм иде.* Ш.Мөхәммәдов

2) Тышкы күренеше, эчтәлеге табигый булмаган; ясалма. *Русларның Пушкин вә Кольцов кеби иң зур шагыйрьләре дә, халык җырларына тәкълид итеп, бертөрле «искусственные песни», ягъни «сонгый җырлар» яздылар.* Г.Тукай. *Тәүфикъ тавышына сонгый җитдилек биреп сөйләп китте.* Ш.Усманов

**СОНЕТ** *и. ит. әд.* Ундүрт шигъри юлдан торган катлаулы строфаларның бер төре, лирик шигырь формасы. *Милли поэзиядә сонетның бер чагылышын Ш.Мөдәррис, Р.Әхмәтҗанов иҗатларында очратырга мөмкин.* А.Әхмәдуллин. *Утызынчы елларның икенче яртысында татар поэзиясендә сонет жанры тернәкләнеп китә.* Т.Галиуллин

**СОНОР** *с. лингв.* Шауга караганда тавыш (музыкаль тон) өстенлек иткән яңгырау тартыклар белән сузыклар арасында торган (тартык авазлар, мәс., [р], [л], [м], [н]). *Татар телендә, мәсәлән, сүз ахырында тартыкларның янәшә килүе – шактый сирәк күренеш (йорт, дүрт, әйт һ.б.), ә иялтемнәрдә шаулы тартык теләсә кайсы сонор аваз белән янәшә килә: чулт, чалт, чырк, гөрс, даңк, дөңк, шарт, гөмберт, мелт, фырт һ.б.* Ф.Хисамова. *Сонор тартыкларны әйткәндә, тон шауга караганда күбрәк катнаша, бу яктан алар сузыкларга якын торалар.* Татар грамматикасы

**СОНУ** *ф.* 1) Кулдагы нәрсәне бирергә дип сузу, тәкъдим итү. *Ул кулындагы чәчәк бәйләмен Хәяткә сонды.* Ф.Әмирхан. *Дәүләтша агай садака сонды, хәзрәт алып дога кылды.* З.Һади

2) Кемнең дә булса теләгенә каршы тоттыру, көчләп кулына бирү, тагу

3) *диал.* Туры, төз рәвешкә китерү, сузу. *Мал да, үлсә, аягын сона шул*

**Сонып тору** Хәзер, сөйләү моментында сону. *Миңа сонып торганың – Аягы төксез бидаяк, – Аны үзеңә ал! – диде.* Дастан

**СОҢ** I *рәв.* **1.** 1) Тиешле вакыттан артка калып, гадәттәгедән кичегеп. *Агач яфрак соң койса, ел авыр килә.* Сынамыш. *Соң гына уянып, ашыкпошык капкалагач, шагыйрь тагын өстәл янына утыра.* И.Нуруллин. *Җыр аның өенә бәйрәм котлавы булып килеп керде. Бер көн иртә түгел, бер көн соң түгел.* Мәдәни җомга

2) Билгеле вакыйга, эш-хәлгә караганда арткарак калып, кичегебрәк, күпмедер вакыт узгач. *Еллар уза бирде. Фәттахның әнисе дә, соңрак әтисе дә дөнья куйдылар.* Н.Дәүли

**2.** *хәб. функ.* Тиешле вакыт, чик узган, кичегелгән булу. *Бер-ике стакан кайнар чәй булганда баш тартмас идем дә бит, вакыт соң инде.* Н.Исәнбәт. *Соң иде инде, Солтангәрәев күз бәйләнгәнче казармага җитәргә ашыкты.* К.Нәҗми

**3.** *и. мәгъ.* Ахыр, азак; нәтиҗә. *Башы яшереннең соңы да батырын була.* Мәкаль. *Һәрвакытта нәкъ сугыш соңында гына күренә торган урядник та, артына городовойны ияртеп, тау башыннан төшеп килә иде.* Ш.Усманов. *Данларгамы --- бу язны? --- Яшьлек соңын, картлык башын бергә китереп бутады...* Р.Фәйзуллин

**4.** *с. мәгъ.* Актык, азаккы, соңгы. *Туган-үскән җирем өчен Соң тамчы каным фида.* Дәрдемәнд

◊ **Соң булса да уң булсын** Эшнең соңга калып башлануына карамый башкарылырга кирәклеге турында. **Соңга калу** Соңару, кичегү. *Мин күзәттем: коньягына быел Соңга калып очты торналар.* Ф.Кәрим. *Таң белән тормакчы булып ятсам да, барыбер соңга калганмын.* Г.Бәширов. **Соң дәрәҗәдә** Бик нык, аеруча. *Хәзер салмак күңелле, хәсрәтле картларның авыр сүзләре астында эшләү соң дәрәҗәдә күңелсезгә әйләнде.* М.Гафури. *Кариев Хәмзә бай ролендә соң дәрәҗәдә яхшы*

*иде.* Н.Исәнбәт. *Берьюлы бу чаклы акча кирәк мине соң дәрәҗәдә шатландырган иде.* Мирас. **Соң сулуларында** *к.* **соңгы сулышында**. *Бичара соң сулуларында шуны гына әйтә алды.* М.Фәйзи. **Соң чиккәчә** *к.* **соң дәрәҗәдә**. *Бу хәл романның тыгыз эчтәлеге, соң чиккәчә кысылган эчке пружинасы, һәр күзәнәге табигатьне, кеше холкын, рухын сындыруга омтылудан килгән сәнгатьчә эшләнешендә күренә.* Т.Галиуллин. **Соң чиктә** Бер дә булмаса, алайга китсә, ниһаять, ахыр чиктә. *Тәрәзә йөзлекләрендә генә түгел хикмәт, соң чиктә йөзлекләрсез дә яшәү мөмкин. Күңелләрдә матурлыкка омтылыш сүлпәнләнүе аяныч.* Р.Мөхәммәдиев

**СОҢ** II *бәйл.* Чыгыш килешендәге сүзләр белән килеп, билгеле бер хәлвакыйганың шунда белдерелгән вакыт үткәч булуын, үтәлүен белдерә. *Кырын эш кырык елдан соң да беленә.* Мәкаль. *Теге көннән соң күпме үткәндер, Сәгыйдулла, печәнлекне урап кайтам, дип чыгып китте.* Ф.Садриев

**СОҢ** III *кис.* Тойгылы җөмләләргә көчәйтү төсмере өсти. *Соң бит бу музыка сүз белән әйтеп бирелгән җырларга караганда мең-мең тапкыр көчлерәк тә, аңлаешлырак та икән ләбаса!* М.Хәсәнов. *Ни өчен шулай рәхимсез соң син, тормыш?* М.Мәһдиев. *Авыл Бәрияне кичерә алмас. Шулай булгач, Нуриәсманың ничек җаны эресен соң?* Ф.Садриев

**СОҢАРУ** *ф. к.* **соңгару**. *Ара-тирә генә соңарган сары яфрак, кыштырдап, агач ботакларына бәрелә-сугыла төшә.* М.Мәһдиев. *Хәбәрдәшенең кем икәнен аңлагач кына, ул бик нык ачынган иде. Ләкин үкенү соңарган булып чыкты.* Т.Галиуллин. *Җавап белән, ахры, соңардым дип, Үз җанымны үзем камчылыйм.* Э.Шәрифуллина

**Соңара башлау** Соңару очраклары ешаю

**Соңара язу** Чак кына соңармый калу. *Фазилә ире янына – Баллыболынга күчеп килергә соңара язды бугай.* М.Маликова

**Соңарып бару** Соңаруга йөз тоту. *Син дә алҗыгансыңдыр, вакыт та соңарып бара.* Н.Әхмәдиев

**СОҢАЮ** *ф. диал.* 1) *к.* **соңгару** (*1 мәгъ.*). *Җәйләр ерак әле. Кояш көн дә Бик соңаеп эшкә уяна.* М.Җәлил

2) Шактый вакыт үтү, көн кичкә таба авышу

**Соңаеп бару** Соңаюга йөз тоту. *Вакыт шактый соңаеп бара. --- Күзләрне инде йокы да баса башлады.* С.Рафиков

**СОҢГАРАК** *рәв.* 1) Бераз вакыт узгач, көттереп, соңыннан, соңга табарак. *Ачлыктан тинтерәгән бичара Мәликә бу сүзләрнең хикмәтенә әйткән уңайга гына төшенмәде. Аның нәтиҗәсе соңгарак килеп чыкты.* К.Нәҗми

2) Гадәттәге, тиешле, кирәк вакыттан кичегеп, арттарак. *Мин өмәчеләрдән соңгарак калып, үз атыма менеп кенә бардым.* Г.Ибраһимов. *Кунаклар гадәттәгедән соңгарак калып килделәр.* Казан утлары

**СОҢГАРУ** *ф.* 1) Билгеләнгән вакыттан соңга калу, тиешле вакытка өлгермәү, кичегү. *Сабан ашлыгы соңгарып чәчелсә дә, озак та үтми тишелеп, яшел хәтфә сыман күпереп үсәргә тотынды.* М.Галәү. *Соңгаруын соңгармады ул, әмма килешенгән урында Мирсәетне инде көтәләр иде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Гадәти вакытыннан артка калу, һәрвакыттагы, тиешле срогында булмау (фасыллар, табигать күренешләре, үсемлекләр һ.б.ш.лар тур.). *Язгы ташу исә бу яклар өчен соңгарып килә: апрельдә башланып июньгә кадәр дәвам итә.* Н.Фәттах

3) Артка калу, узган вакытны кимрәк итеп күрсәтү (сәгать тур.). *Сәер ашкыну бар миндә, Көтәм дигәндә иркәм. Сәгатем соңгара, дим дә Өч сәгать алдан китәм.* З.Нури

4) Тәүлек вакыты инде соң булу, кичкә таба бару

**Соңгара башлау** Соңгару очраклары ешаю

**Соңгара төшү** Бераз соңгару. *Соңгара төшеп, директор да кагылды аның янына.* Р.Мөхәммәдиев

**Соңгара язу** Чак кына соңгармый калу

**СОҢГЫ** *с.* **1.** 1) Бер эзлеклелектә торган бериш нәрсәләрнең иң ахыргысы; азаккы. *[Хатынның] өч баласы бар икән. Соңгы икесе игезәкләр – өчәр яшьлек кыз балалар.* М.Хәсәнов. *Институтның соңгы курсында дәүләт имтиханнары, диплом яклау артыннан йөреп никадәр борчылынды, кайгырылды!* М.Вәлиев

2) Иң ахырга калган; ахыргы. *Хатының соңгы юлларын җырлар белән тутыра.* Ф.Кәрим. *Траптан иң соңгы кеше булып ике кулына ике дәү чемодан тоткан яшь бер ханым чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

3) Бөтен булган нәрсәнең кулда калган иң актыккысы һәм бердәнбере. *Бик арзан гына тегү машинасы алмакчы икән. Белми ул кешеләр шәһәрдә --- бер кадак майга үзләренең соңгы бишмәтләрен биреп җибәргәнне.* Н.Дәүли. *Солдатлар ачулы, --- сугыша башласалар, тешләрен кысып, соңгы граната, соңгы патроннары беткәнче сугышалар.* Г.Әпсәләмов

4) Башка культураларга караганда соңрак чәчелә, утыртыла яки өлгерә торган. *Соңгы культураларны җыеп алырга керешү*

5) Шушы араларда, күптән түгел генә булып узган. --- *Бер акбүз бияләре булып, бу соңгы өч елда үзеннән алга һичбер атны чыгармаган иде.* Г.Ибраһимов. *Соңгы вакытларда матбугатта парча дип исемләнгән язмалар еш күренә башлады.* Г.Рәхим

6) Әле генә телгә алынган, әйтеп үтелгән, иң ахыргы. *Малайның соңгы сүзе Гөлсем апага мөлдерәмә стаканны ташыткан тамчыдай тәэсир итте.* Г.Гобәй

7) Әле генә барлыкка килгән, чыккан, иң яңа. *Ишектә соңгы мода белән киенгән, йөзенә кара вуаль япкан зифа буйлы бер туташ күренә.* К.Тинчурин. *Соңгы хәбәрләр*

8) Алда булганнарны йомгаклый торган, катгый, кистереп әйтелгән. *Федосеев дамбасын Гөлшаһидә тыелган, бозарга ярамый торган соңгы чик дип уйлый иде. Ләкин бүген ул менә шушы соңгы чикне дә бозды.* Г.Әпсәләмов. *Аксак Тимер гаскәренең башлыгы соңгы әмерен җиткерде: – Хан кызы Рабиганы миңа тотып бирсәгез, мин сезне азат итәрмен.* Татар халык иҗаты

9) Иң ахырда, башка чара таба алмагач, чарасызлыктан эшләнә торган. *Соңгы чара нинди дә булса батырлык кылу иде.* З.Мәхмүди

10) Хәлиткеч. *Беренче октябрьдә урыс гаскәрләренә соңгы штурмга әзерләнергә әмер килә.* Ф.Хуҗин

11) Абруйсыз, дәрәҗәсез, сүзе үтми торган. *Ул үз эшендә соңгы кеше түгел*

12) Үлем, һәлакәт алдыннан булган. *Соңгы җырым палач балтасына Башны тоткан килеш языла.* М.Җәлил. *Соңгы сүзе итеп, каберемә кызыл йолдыз утыртырсың, диде дә беләгемә ятып җан бирде.* М.Фәйзи. *– Әни-и! – дигән тавыш ишетелгәндәй булды. Бу газиз баласының ул ишеткән үзәк өзгеч соңгы тавышы иде.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Иң ахырдан күрсәтелгән, әйтелгән нәрсә. *Бу соңгылары – иртә белән кояш күтәрелгәч тә башланачак кызуга каршы алдан ук чара күреп куйган халык.* Ш.Усманов. *Күпләр, үзләренең бу урыннан күчүләрен белдереп, ата-аналарына, дусларына хат язарга тотындылар. Соңгылары арасында мин дә бар идем.* Г.Галиев

2) Башка кабатланмый торган эш, гамәл, очрак. *Сибгат ага белән йөргән бу сәяхәт соңгысы булды.* М.Мәһдиев. *[Кыз:] – Мин бу эшне башка эшләмим, бу – соңгысы, – диде.* Казан утлары

◊ **Соңгы бурыч** Үлгән кешегә хөрмәт йөзеннән аның үләр алдыннан әйткән теләген үтәү яки башка яхшылык эшләү. **Соңгы сулышына кадәр** Үлгәнче. *Кеше дә бөтен көчен туплап тырыша, соңгы сулышына кадәр аяк терәп көрәшә.* М.Хәсәнов. **Соңгы сулышын алганда** *к.* **соңгы сулышында**. *Соңгы сулышларын алганда да, дустымның кулында тальяны булган.* Татарстан яшьләре. **Соңгы сулышында** Үлем алдыннан. *Тик соңгы сулышында көчкә генә әйткән сүзе шул булды: – Миннән бәхил бул!* Н.Исәнбәт. **Соңгы юл** Кабергә озатылу, күмелү турында. *[Әбисе:] – Сабыр, улым, сабыр! Бер сайрасыннар әле. Бабаң да соңгы юлыннан торналар сайраганны тыңлап узган, – диде.* Г.Бәширов. *Халык агымы, шагыйрьнең соңгы юлын кыскарта барып, һаман алга таба шуыша.* И.Нуруллин. *Сугыш елларында вафат булган кешеләрне хисапка алу, соңгы юлга озату (бигрәк тә кыш көне) зур проблемага әверелгән.* Татарстан яшьләре

**СОҢГЫЛЫК** *и. анат.* Кешеләрдә һәм имезүче хайваннарда: ана карынындагы яралгының бала туганнан соң төшә торган тышчасы; бала яткылыгы; чүп (терлектә). *Соңгылыкта ана организмындагы кан юллары кендек аша яралгының кан юллары белән тоташа.* Биология. *Бала тугач, бераздан соңгылык та төште.* Сөембикә

**СОҢЛА́У** *ф. к.* **соңгару** (*1 мәгъ.*). *Моңсу гына күзгә бакты Соңлап чәчәк аткан бер гөл.* Г.Мөхәммәтшин

**Соңлап калу** Берәр сәбәп аркасында соңлау. *Бәхетсезлекнең бер төнгә соңлап калуы, бәхетнең бер төнгә китми торуы кеше өчен үзе зур бүләк түгелмени?* М.Кәрим

**Соңлый төшү** Бераз соңга калу, беркадәр соңлау

**СОҢРА** *рәв.* Соңыннан, ахырдан. *Габдулла башта төрле урында йоклап, соңра даими урын иясе булып киткән.* И.Нуруллин. *Соңра, мәхәббәт алмашып, арада сөю хатлары йөри башлагач, ул да йомшады.* А.Гыйләҗев

**СОҢЫНА́ЧА** *рәв.* Ахыргача, ахырынача, азакка кадәр. *Бу тормыштан алып булганның Бөтенесен телим алырга, Һәм ашыгам бирә алганны Соңынача биреп калырга.* З.Мансур

**СОҢЫНДА** *бәйл. сүз.* Нинди дә булса эш-хәл узгач, берәр вакыйгадан соң. *Кырга чык, яңгыр соңында һәр тугайдан җил чыгар.* Ш.Бабич. *Садакалар соңында бөтен мәҗлес кул күтәреп дога кылганда да, явыз шайтан аның күңеленә һаман шул шелтәләрне сала торды.* Г.Ибраһимов

**СОҢЫННАН** *рәв.* **1.** Күпмедер вакыттан соң, билгеле вакыт үткәч; ахырдан. *Үзебезнең ярты десятина тарыны иң соңыннан урып-сугып алдык.* М.Гафури. *Әбисе гел чакырусыз калмасын, соңыннан сүзе булмасын өчен, телеграмманы туй көнне иртән генә сугарга булды.* Ф.Садриев

**2.** *бәйл. функ.* Башка берәр эш-гамәл үтәлеп беткәч, берәр кеше яки берәр нәрсәдән соң. *Килер апрель, соңыннан безгә – майлар, Бирер һәркемгә ләззәт ошбу айлар.* М.Гафури. *Закир – әүвәл учитель булган, соңыннан аны ташлап, страховой агентлык итә башлаган өйләнмәгән бер егет.* Ф.Әмирхан

**СОҢЫНТЫН** *рәв. диал. к.* **соңыннан** (*1 мәгъ.*). *Менә шулай, соңынтын сүз булмасын өчен, алдан киңәштабышлашып кую яхшырак.* С.Рафиков. *Атасы балта остасы булган да, соңынтын эшкә киткән җирдән кайтмаган.* М.Фәйзи

**СОП-** Кайбер сыйфатлар белән килеп, шуның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә (мәс., *соп-соры*)

**СО́ПКА** *и. рус* 1) Байкалның аръягында, Ерак Көнчыгышта һәм Казахстанда зур булмаган урмансыз тау түбәләренең гомуми атамасы. *Амур аръягында да, үзебезнең якта да сопкалар кызыл нурга чумганнар.* М.Мәһдиев. *Фаяз хатларында тирә-якта каракучкыл урманнар белән капланган сопкалар булуын яза иде.* С.Шәмси

2) Камчаткада һәм Курил утрауларында сүнгән һәм хәрәкәттәге вулкан

**СОПРА́НО** *и. ит. муз.* 1) Вокал сәнгатендә хатын-кызларда һәм малайларда гына була торган иң югары нечкә тавыш. *Лиза үзенең кечкенә, ләкин мәхәббәтле сопраносы белән бер романсның башын җырлап җибәрде.* Ф.Әмирхан. *Бик сирәк тавыш бит альт, сопранолар тулып ята.* Сөембикә

2) Музыка әсәрендә шушы тавыш өчен язылган партия; катнаш хорда югары партия

3) Шундый тавышлы җырчы

**СОРАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сорау** II

2) Таләп ителү, кирәк булу. *Шушы байлыкны тудыручы, аны нәфис җанландыручы булу өчен тагы да күбрәк нәрсәләр сорала.* Һ.Такташ. *Режиссёрдан, иң беренче чиратта, әсәрнең шул урыннарын калку итеп бирүе сорала.* Ю.Сафиуллин

**СОРАМЧАК** *с.* Сораныргa (*1 мәгъ.*) яратучан, сорануучан. *Күршеләребез бик сорамчак*

**СОРА́МЫЙ** *рәв. к.* **сорамыйча**

**СОРА́МЫЙЧА** *рәв.* Рөхсәтсез, рөхсәттән башка, сораусыз. *[Әсма:] – Кит, юньсез! Кеше әйберенә сорамыйча ка-*

*гылалармыни? Ризыкны тотарга ярамый! – дип, --- сугып җибәрде.* М.Галәү

**СОРАНУ** *ф.* 1) Кешедән һәрвакыт нәрсәдер сорау. *Аннан соң, Габдулла апаларына сирәк барганга, барганда да сораныргa яратмаганга, аның хәленнән бик үк хәбәрдар да булмаганнар.* И.Нуруллин

2) Хәер эстәү, теләнү. *[Бәдри Җәмиләгә:] Бу – шәһәр җире, монда беркем дә белми, алай-болай сорану бер дә гаеп эш түгел.* М.Гафури. *Үкереп торган төп йорттан шулай кимсетеп чыгарсалар да, Аллага шөкер, --- капчык асып сораныргa чыкмадылар.* Г.Бәширов

**Сорана башлау** Сораныргa тотыну

**Соранып йөрү** Төрле җирдә, күптәннән бирле, гел сорану. *Соранып йөрергә ул бер бахыр түгел лә... Хөкем иясе, хөкүмәт кешесе.* М.Кәрим. *Тегесе кирәк, бусы кирәк дип, әллә кемнәрдән әллә нәрсәләр соранып йөрмәде: көннәрдән бер көнне бульдозер алып кайтты да өй артындагы бәрәңге бакчасының яртысын кызыл балчыкка кадәр сөздереп ташлады.* Ф.Яруллин

**Соранып тору** Даими рәвештә сорану; хәзерге моментта сорану. *Шәһәрдә аларны базар янындагы урам чатларына утыртып чыкканнар: һәркем шул урынында хәер соранып торырга тиеш булган.* Ә.Сафиуллин

**Соранып чыгу** Бөтенесеннән сорану

**СОРАНУЧАН** *с. к.* **сорамчак**

**СОРАНУЧЫ** *и.* Теләнче, хәер эстәүче, саил. *Юк, мин соранучы түгел, баш кода булып килдем, ди.* Әкият. *Мин инде мин түгел, гадәти бер йортсыз-җирсез, мал-туарсыз соранучы, теләнүче.* Т.Галиуллин

**СОРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сорау** (*1, 2, 3 мәгъ.*)

2) Берәр нәрсә бирүне яки эшләүне үтенү, шундый үтенеч белән мөрәҗәгать итү. *Бусы аның чын манифест та түгелдер әле. Губернаторга чын манифест соратып прошение языйк.* К.Нәҗми

3) *этн.* Туй йоласы буенча, кызга яучы аша тәкъдим ясату; кыз яучылау. *Борынгылар әйткәннәр, кем икәнеңне беләсең килсә, кыз сорат, дигәннәр.* А.Шамов. *Килен чагыннан ук Көмешбикә биләмдә йөрергә әвәс булды, үзен соратырга яучы килгәндә дә, әллә кая йөреп калды бит ул.* М.Кәрим

**Сората башлау** Соратуны чиратлы җитү. *Бән исә, кыз сората башлагач, Сабирны кып-кыска кайтармыш идем. Остабикә дигән нәрсә: «Шушындый бай хаҗига да кыз бирмәгәч, кызны кемгә бирерсең? ---», – диеп гаҗиз иткәч бирдек иде.* Г.Камал

**Соратып карау** Соратуы юлын сынау. *--- әгәр дә бу сәфәремнән сәламәт йөреп кайтсам, шул Хикмәтулланың кардәше Бибимәрзияне соратып карармын, шаять, бирсә кирәк.* Г.Камал. *Кемнәрне генә соратып карамады хатынлыкка Гобәйдулла.* А.Хәлим

**Соратып кую** Алдан ук сорату

**Соратып тору** Һәрвакыт, һәрчак сорату

**СОРАТУЧЫ** *и.* 1) *этн.* Яучылаучы, яучы җибәрүче. *Кызны соратучылар күп булды*

2) Соратып алучы, заказ бирүче, сатып алучы, кулланучы. *[Хуҗа:] Мин хезмәтчеләремнең яртысын чыгарам, --- бер дә ситсыны соратучы юк.* Г.Тукай

**СОРА́У** I *ф.* 1) Берәр нәрсәне белергә, ачыкларга теләп мөрәҗәгать итү. *Әти Сафа абыйдан беренче чәй янында ук сорар: – Я, берәр эш киләме бу малайның кулыннан?* Г.Бәширов. *Гани абзый исә кайсы әйбернең кайда саклануын, җиде төн уртасында уятып сорасыннар, эһ тә итми әйтеп бирә.* Ш.Рәкыйпов

2) Укучыларның белемен тикшерү өчен, элек өйрәнгәнне сөйләп-аңлатып бирергә кушу. *Икенче дәрес – география укыту методикасы дәресе иде. Анда да Гыйззәтуллиннан сорадылар.* М.Мәһдиев

3) Берәр нәрсә бирүне яки эшләүне үтенү, шундый үтенеч белән мөрәҗәгать итү. *Шулай да Корбангали, йомыш сорап, әҗәткә алып, аны йончытмады.* М.Кәрим. *Кариевтан «Казан шәһәренең мөселман җәмгыяте хәйриясе» утырышын имитацияләп күрсәтүен сорыйлар.* И.Рәми

4) Кызның ата-аналарыннан яки якын кардәшләреннән аны кияүгә бирергә ризалыкларын үтенү; кыз яучылау. *Уракка чыгар алдыннан, кыр эшләре башланганчы, авылда кыз сорап яучы җибәрү гадәте юк, чөнки кыз сораучыларга җавап бер генә...* М.Галәү. *[Ир:] Кыз сорарга барырга исәп, әмма башкода булырдай кешем – әтием дә, абыйлар да юк.* Казан утлары

5) Таләп итү, катгый таләп кую. *Без аңардан икеләтә артык сораячакбыз.* Р.Ишморат

6) Алда нинди дә булса эш тору, нинди дә булса бер хәлне көтү. *Болында ат корсагыннан үлән, ул чалгы сорый; кырда иген өлгергән, ул урак тыгуны көтә.* Г.Галиев. *Дөньяда һәрбер нәрсә камиллеккә омтыла, үзенә тиң ритм, көй сорап тора.* Р.Низамиев

7) Берәр нәрсә таләп итеп дау күтәрү. *Кымыз фабрикаларындагы эшчеләр хезмәт вакытын сигез сәгатькә калдыруны сорыйлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Үз араларыннан шундый бер тәвәккәл йөрәкнең килеп чыгуын гына көткән Тигәнәле кешеләре аяк терәп җир сорыйлар.* К.Нәҗми. *Табигать көне буе дулады, ул нәрсәгәдер риза түгел. Кешеләрдән нәрсәдер сорый кебек.* М.Мәһдиев

8) Бәяне кую, хак билгеләү. *Центнерына мең сум сорау*

9) Кирәк булу, зарур булу, таләпителү. *Бу эш зур тырышлык сорый*

10) *к.* **сорану** (*2 мәгъ.*). *Мондый җиде төн уртасында, бер телем икмәк сорап, кайларда йөри икән Аксюша тути?* Г.Әпсәләмов

**Сорап алу** Тиз генә сорау

**Сорап бару** Һәр очракта, рәттән, эзлекле рәвештә сорау

**Сорап бетерү** Бөтенесен дә сорау

**Сорап йөрү** Күптәннән бирле сорау; һәркемнән, һәр җирдә сорау. *Аннан инде син райком, обком, министрлык бусагасын таптап, кеше сорап йөр.* Т.Гыйззәт. *Ибәт абзыгайны белгән идегез, ике ел --- Нурыйгаян абыстайны сорап йөргән иде.* З.Һади

**Сорап калу** Сорарга өлгерү, вакытында сорау. *Ата-бабаларының исемнәрен сорап каласы булган.* Д.Салихов

**Сорап карау** Булу-булмавын сынар өчен сорау, сорау алымын сынау.

*Илбарис Рамазанович, үзебезгә бер баржа сорап карасак, барып чыгар иде микән?* С.Сабиров. *Шушы хакта яным-да басып торучы ике әрмән егетеннән сорап карадым.* М.Нурулла

**Сорап кую** Көтмәгәндә, кинәт со-рау; бер мәртәбә генә сорау. *– Ни бул-ды соң сиңа? – дип, йомшак кына со-рап куйды [Гөлзифа].* Р.Төхфәтулллин. *– Син җыр яратасыңмы? – дип сорап куйды ул, уйламаган җирдән.* Р.Мө-хәммәдиев

**Сорап тору** Даими рәвештә, һәрва-кыт сорау; озаклап сорау; хәзер сорау. *Аталары булган җегетләрнең үзлә-реннән сорап тормыйлар, көне килсә, тоталар да бер төшкә башкода җибәрәләр.* Г.Ибраһимов. *Сорап тора-сы да юк иде: кызның кырыс йөзеннән үк элемтә урнаштыра алмавын мин ачык аңладым.* А.Тимергалин

**Сорап утыру** *сөйл. к.* **сорап тору**. *Җитмәсә, сорап утырган буласың. Күктән төшмәгәнсеңдер ич: күргән-сеңдер, ишеткәнсеңдер.* Н.Фәттах

**Сорап чыгу** Һәрберсеннән сорау; башыннан ахырынача сорау

**Сорый башлау** Сорарга тотыну. *Максудовта алачагы бар адәмнәр һәр-кайсы, вексель яки распискасы буенча судка биреп, хакын сорый башлады.* Ш.Мөхәммәдев

**Сорый тору** Әлегә сорау; озаклап сорау. *Бер дә бер көнне боларның ата-лары, бик күп сорый торгачтын, бо-ларга да бер елга рөхсәт бирде.* Әкият

**СОРА́У** II *и.* **1.** 1) Җавап яки аңлатма таләп итә торган сүз, мөрәҗәгать. *– Ә кемнеке булсын, минеке булмый-ча? – Хафиз сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды.* Ф.Хөсни. *– Ни булды, әни? Ни эшләп тагын шул тәрәзә тө-бендә утырасың? – дип, сорау артын-нан сорау яудырам.* Р.Мөхәммәдиев

2) Мәсьәлә, караласы, ачыкланасы нәрсә. *Бу сораулар күпләрне борчый-дыр дип уйлыйм (шулай булса, димәк, язуым аклана).* Р.Фәйзуллин. *Гомумән, дини сорауларда аларның күбесенең әзерлекләре ташка үлчим.* А.Галимов

3) *юр.* Тикшерү эшендә: хакыйкать-не ачу өчен, вакыйгага кагылышлы мәгълүматны сөйләтү; *русчасы*: **до-прос**. *Иртән сыек кына бер стакан чәй эчерткәч, тагын сорау алырга ча-кырдылар.* А.Гыйләҗев. *Бик күп баш-ка тоткыннардан аермалы буларак, Гомәр Галигә карата сорау беркетмә-ләре юк дәрәҗәсендә.* Р.Мостафин

4) Нәрсәгә дә булса карата ихтыяҗ; таләп. *Ф.Фасеев аңлатмалы сүзлек төзүнең халык соравы буенча баш-карылуын ассызыклап күрсәтеп үтә.* Ф.Сафиуллина. *Китапларга сорау га-ять зур булган, һәм татар китабын сатып йөрүчеләр аларны үз кавемдәш-ләре арасында гына түгел, ә башка ту-гандаш халыклар арасында да тарат-кан.* Мәдәни җомга

5) *махс.* Кулланучының билгеле бер вакытта, мәгълүм урында хезмәт күр-сәтүләрне яки әйберләрне сатып алыр-га теләве һәм мөмкинлеге; ихтыяҗ, таләп; *русчасы*: **спрос**. *Сугыштан соң затлы мехларга сорау тагы да артты.* Ә.Еники. *Товарга сорау арткан саен, аның бәясе күтәрелү*

**2.** *с. мәгъ.* Сорау (*1 мәгъ.*) белдерә торган. *[Автор] Фикерен көчәйтү мак-сатында тойгылы һәм сорау җөмлә-ләрнең мөмкинлекләрен киң файдала-на ---.* В. Гарифуллин

◊ **Сорау алу** Җинаятьне һ.б.ш. тик-шергәндә, гаепләнүчене, шаһитны һ.б. сөйләтеп, мәгълүмат туплау. *Страж-никларны ияртеп, становой да килде. Шуннан сорау ала башладылар.* М.Га-ләү. *Донос аркасында туу турында-гы таныклыкның сере фаш ителгәч, 1907 елның башында тикшерү, сорау алу башлана.* И.Нуруллин

**СОРА́У БИЛГЕСЕ** *и. лингв.* Җавап яки аңлатма таләп иткән җөмләдән соң куела торган пунктуация билгесе (?). *Сорау билгесе кебек катып калган гәү-дәсе әйтерсең тормышның, гомернең болай тәмамлануына кемнәндер нин-дидер җаваплар көтә иде.* Р.Гариф

**СОРАУЛЫ** *с.* **1.** 1) Сорау белдерә торган, берәр сорауны эченә алган. *Гос-ман сораулы карашын сыйныфташына юнәлтте.* Р.Мөхәммәдиев

2) Үтенүле, үтенү белдергән, үте-нү аңлаткан. *[Гыйльфан] сораулы бер кыяфәттә Ямашевка текәлде.* А.Ра-сих. *[Фуат:] – Әкәмәт кызык бит, әби! Без боларны сездән язып алмыйча калмабыз ---, – һәм аңа сораулы кара-шын төбәде.* Э.Касыймов

**2.** *рәв. мәгъ.* Сорау белән, сорау бел-дереп. *Фаезнур исә, килешеп бетәр микән соң дигәндәй, сораулы карап куй-ды.* А.Әхмәтгалиева

**СОРАУЛЫК** *и.* Берәр мәсьәлә бу-енча мәгълүмат туплау өчен төзелгән сораулар исемлеге. *1958 елда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сорау-лык» басылып чыга.* Ф.Сафиуллина. *Батыршаның патша тикшерүчеләре төзеп биргән утыз җиде сораудан торган «сораулык»ка җавап язганы билгеле.* Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. *Диалектологик сораулык*

**СОРАУСЫЗ** *с.* **1.** Сорауны эченә алмаган яки турыдан-туры сорау сүзе яки җөмләсе булмаган (дәреслектәге мәсьәләләр, сөйләмдәге җөмләләр һ.б.ш. тур.)

**2.** *рәв. мәгъ.* Рөхсәтсез, сорамыйча. *Конторда Әхмәди алдында кычкы-рып сүз дә сөйләмиләр һәм аннан со-раусыз һичбер эш тә эшли алмыйлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Шулай битен ышкый-ышкый бара торгач, апаларының фа-тирларына барып җитеп, сораусыз-нисез барып керә.* М.Гафури

**СОРАШТЫРУ** I *ф.* 1) Өстән-өстән генә, бераз гына сорашу. *Марфа түти, гадәтенчә, авыл хәлләрен сораштыра.* М.Вәли-Барҗылы

2) Кат-кат сорау бирү, сорашу. *[Ру-хия:] Әнине чакыртып сораштыр-ганнардырмы, юкмы, анысын әйтә алмыйм, минем белән сөйләшмәделәр.* В.Нуруллин. --- *Куанычы чиктән аш-кан кешедәй өзгәләнә-өзгәләнә шәһәр хәлләрен сораштырган кунагын җен алыштырды диярсең.* Р.Мөхәммәдиев. *Психиатр дигәнебез --- чирнең гому-ми агышы, ашказанына кабул ителгән даруларның күңелгә хуш килү-килмәве турында тәфсилле итеп сораштырыр-га керешә.* Т.Галиуллин

3) *юр.* Сорау алу, тикшерү. *Бер унбиш-егерме көннән үзебезнең әрмис-ләрне күрдек. --- Аннары шул: сораш-тырдылар, кәгазь яздылар, кул куйдыр-дылар...* М.Мәһдиев

**Сораштыра бару** Рәттән сораштыру. *Алып Бәргән очраган бер кешедән шулай сораштыра барды.* Р.Батулла

**Сораштыра башлау** Сораштырырга тотыну. *Әбүзәр абзый Галина Петровнаның исәнлеге-саулыгы турында сораштыра башлагач, Аксюша түти бик авыр көрсенеп куйды.* Г.Әпсәләмов

**Сораштыра тору** Кат-кат сораштыру; әлегә сораштыру. *Сораштыра торгач, хатынның эче авыртканы беленде.* Г.Әпсәләмов

**Сораштырып алу** Тиз генә, бераз гына сораштыру. *Ул Мортазаның хәл-әхвәлен, кайсы институтта укыганын, кайда эшләгәнен, ничек яшәгәнен сораштырып алды.* М.Маликова. *Юлны рәтләп белмиләр, картага караган булалар, бер-ике тапкыр тукталып, сораштырып та алдылар.* Т.Галиуллин

**Сораштырып бетерү** Ахырына кадәр сораштыру. *Сораштырып бетергәч, Улечка баланың йөрәген, үпкәсен тыңлап карады.* Н.Фәттах

**Сораштырып йөрү** Күптәннән, һәр җирдә сораштыру. *Алай да исемдә, якташым --- Гурий Тавлин белән йорттан йортка кереп: «Сездә Г.Ибраһимов китаплары калмадымы?» – дип сораштырып йөргән идек.* А.Гыйләҗев

**Сораштырып карау** Сораштырырга тырышу. *Ул Рафигадан Бәхти турында, аларның кайчан, ничек очрашулары, ничек дуслашып китүләре турында, Бәхтинең кем булуы турында сораштырып карамакчы булды.* Н.Фәттах. *Ак этләр турында әнисеннән дә сораштырып карады, ләкин аңлаешлы җавап ала алмады.* И.Хуҗин

**Сораштырып китү** Рәттән сораштыра башлау. *Каз куучы әбиләрне сөйләндереп торды. --- ыштансыз малайларның исемнәрен сораштырып китте.* Р.Батулла

**Сораштырып тору** Әле, күз алдында сораштыру; бертуктаусыз сораштыру. *Кибетче кыздан да сораштырып торам: безнең апа шул көннән соң бу кибеткә башка кермәс булган.* Р.Мөхәммәдиев

**Сораштырып утыру** *сөйл. к.* **сораштырып тору**. *Кичә Россиядән килеп монда яшәүче хатын, Кэролиннарга кереп, бик күп сораштырып утырды.* Ф.Яруллин. *Шактый озак Чечнядагы хәлләрне сораштырып утырды.* З.Мәхмүди

**Сораштырып чыгу** Бөтенесен дә, барысын да сораштыру. *Соломон Моисеевич безнең һәрберебездән сораштырып чыкты: кайдан килдегез, кайда укыдыгыз, диде.* Н.Фәттах. *Әни акчаны кай тирәдә төшерүен дә чамалый, авыл кешеләреннән дә сораштырып чыктылар: табучы гына дәшми.* Р.Шәяхмәтова

**СОРАШТЫРУ** II *и.* 1) *юр.* Җинаять эшендә тикшерү эшләре алып бару; *русчасы*: **дознание**. *– Хөрмәтле судья! Минем яклanучым урынынннан да, сораштыру вакытында да җинаять кылынган вакытта, гомумән, шәһәрдә булмавы турында эзлекле рәвештә әйтә килде, – диде адвокат.* Ә.Сафиуллин

2) Анкеталау ысулы; җәмәгатьчелек фикерен белү өчен, сораулар бирү. *Җыр сәнгатенә кагылышлы кызыклы сораштыру да бар. Үз фикереңне халыкка җиткерергә телисеңме?* А.Әпсәләмова

**СОРАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **сорау** I (*1–3 мәгъ.*). *Һәр көн төрлебез шәһәрнең төрле җиренә йөреп, эш эзләп карыйбыз, кайда нинди эш барын сорашабыз.* М.Гафури. *Юлдашларым җанланды, автобус бәхәс учагына әйләнде, сорашу китте.* А.Гыйләҗев

2) Берәр нәрсә турында белергә тырышып, кабат-кабат сораулар бирү. *Закир атасыннан яисә анасы Хәернисадан сорашырга булды.* Г.Ибраһимов. *Дөресрәге, абзый туктаусыз сораша, ә кызый аска гына караган килеш, кыска-кыска җаваплар бирә.* Р.Төхфәтуллин

3) Кемнең дә булса хәле белән танышу; белешү. *Мәрәһим очраган берәүгә ачык елмаеп, ихлас сәлам бирде, ләкин, тукталып, берәүдән дә хәл-әхвәл сорашмады, атлавын белде.* М.Кәрим. *Лагерьда: «Нигә утырттылар?» – дип сорашу, кызыксыну юк, ярамый да, әмма яшьтәшләр арасында сер каламыни?..* А.Гыйләҗев

4) Хәер сорап йөрү, теләнү, сорану. *Мин, ди, бик яшьли ятим калдым, ди [бабай]... Караучым булмагач, хәер сорашып тамак туйдыра идем, ди.* Г.Ибраһимов

**Сораша башлау** Сорашырга тотыну. *– Кала күрергә килдегезме, кодалар? – дип сораша башлады Ишбирде.* М.Кәрим. *Кызылармеецлар килүчеләрне чолгап алып сораша башладылар.* Ш.Усманов

**Сораша тору** Әлегә сорашу; әледән-әле, регуляр рәвештә сорашу

**Сорашып алу** Тиз генә сорашу, бераз гына сорашу. *Җиңги ятыр өчен урынны ничек җәяргә кирәклек турында да сорашып ала.* Г.Толымбай

**Сорашып йөрү** Гел, озаклап, һәр җирдә сорашу. *Җомга көн төш вакытына кадәр Хәерниса җиңги авыл буйлап сорашып йөрде.* М.Мәһдиев

**Сорашып карау** Сынау максаты белән сорашу. *[Гариф:] Син әнә беркөнге чыптачы карттан сорашып кара әле: йокларга еш туры киләме икән аңа?* М.Галәү

**Сорашып тору** Даими, гел яки хәзерге моментта сорашу; сорашу белән мәшгуль булу. *Бүтәнчә сорашып тормадылар, өчесе дә шунда ук киенеп, Полина белән бергә почта йортына киттеләр.* М.Кәрим. *Сораша торгач, Сәмигулла монысын да аңлады.* М.Мәһдиев

**Сорашып чыгу** Барысын да сорашу; барысыннан да сорашу

**СОРГАВЫЛ** *и. монг. тар. хәрби* Арьергард. *Соргавылны күргәндә, Идегәй ир аны әйтте: – Әй соргавыл, соргавыл, Туп-туп баскан, туп баскан, Тояглы җирне тумырган. Тумырылып яткан җир күрдем.* Дастан

**СО́РГО** *и. лат.* Кыяклылар семьялыгыннан кукурузга охшаш, җылы яратучан терлек азыгы культурасы; Мисыр тарысы, Судан үләне. *Алай гынамы, киләчәктә сорgoны дөге белән кушып, республикабыз кырларында моңа кадәр билгеле булмаган бөртекле ашамлык культурасы үстерә башлавыбыз да бик ихтимал.* Ватаным Татарстан

**СОРГЫЛТ** *с. ким.* 1) Соры төсмере булган, соры төскә якын. *Менә без чын татарның үзен күрдек. Соргылт кашлы, сипкелле, таза куллы, төп шикелле бер малай.* М.Мәһдиев. *Сафиулла аннары гына, соргылт күзләрендә нindiдер күңел өнәмәс очкыннар чагылдырып әйтә.* Р.Төхфәтуллин

2) Берәр төс белдергән сүз белән килеп, шуның соры төсмерле булуын белдерә. *Бераз юл алгач, каршы якта үзәнлектә утырган завод морҗалары һәм алар өстендә бөтерелгән соргылт сары төтен болыты күренде.* Э.Касыймов. *Тән тиресе соргылт яшел төстә, күзләре чит планета кешесенеке кебек түгәрәк.* Ватаным Татарстан

**СОРГЫЛТЛАНУ** *ф.* Соргылт төсмер барлыкка килү; соргылт төскә керү, соргылтка әйләнү. *Йөзе карасу соргылтланган, үлем аңа үзенең кара пәрдәсен япкан инде.* Х.Камалов

**Соргылтлана бару** Торган саен соргылтлану, акрынлап соргылтлану

**Соргылтлана төшү** Бераз соргылт төскә керү

**Соргылтланып китү** Соңгы арада бераз соргылтлану

**Соргылтланып тору** Беркадәр соргылт булып күренү

**СОРНАЙ** *и. фар.* Озын быргы рәвешендәге тынлы уен коралы. *Чиркәсләрнең моңлы көен чалды сорнай. Хәсрәт белән тибрәнде кыл, янды курай.* Ф.Бурнаш. *Күп тә үтмәде, сорнай, думбра, курай, кубызише уен коралларын тотып, арткы ишектән көйчеләр килеп керде.* Н.Фәттах

**СОРНАЙЧЫ** *и.* Сорнайда уйнаучы, сорнай остасы. *Үзе дә оста сорнайчы булганга гына түгел, башка берәү уйнаганда да, ул шулай әсәрләнә.* Р.Батулла. *Аларның колгага менүчеләре, бауда йөгерүчеләре, сорнайчылар, көрәшчеләр, хәтта кәмитчеләренә чаклы – барысы да орчык буе гына адәмнәр, ди.* В.Имамов

**СОРТ** *и. фр.* 1) Товар, эшләнмә һ.б.ш. бериш әйберләрнең төрдәшләреннән үзенең сыйфаты, кыйммәте һ.б. белән аерыла торган төре. *Казылыкчы командир, итләрнең сортларын аера белгән төсле, хатын-кызларны да сортларга бүлә белә иде.* К.Тинчурин. *Баштарак ул шул пычкы чүбеннән дә арынып бетмәгән такталарны сортларга, ассортиментларга бүлеп, эстакададан штабельләргә озатып бара иде.* М.Хәсәнов

2) Селекция юлы белән чыгарылган, морфологик, физиологик, генетик һ.б. үзлекләре нәселдән нәселгә күчү сыйфатына ия булган үсемлекләр җыелмасы. *Кәрим абыйда – крыжовник, әтидә яңа сорт кызыл карлыган бар.* М.Мәһдиев

3) *сөйл.* Теләсә нәрсәнең бер төре

4) *күч.* Башкалардан нәрсәсе беләндер аерылып торган, артыграк яки кимрәк күрелгән катлау, даирә. *Алардан кала икенче һәм өченче сорт кунакларга басу капкасы ачарга чыгучы малайлар шактый азайган иде.* Г.Камал. *Бездән булмый ул, без андый сорт түгел, беләсез.* Х.Камалов

**СОРТА́МЕНТ** *и. фр.* Билгеле бер җитештерү тармагында яки предприятиесендә эшләп чыгарылган эшләнмәләрнең төрләре, сортлары җыелмасы. *Прокат кисемнәренең формасы, үлчәме, үлчәм берәмлеге, тайпылыш чиге күрсәтелгән исемлеге сортамент дип атала.* Төзү материаллары

**СОРТИРО́ВКА** *и. рус махс.* 1) Нәрсәнедер сортлау, аеру, чистарту эше. *Иртүк берничә машина юлга кузгала. Алар, берничә районга кереп, почтаны калдыра. Анда янә сортировка эше башкарыла.* Э.Фатыйхова. *Беренче сортировка линиясе августларга ачылачак, аннан соң икенчесен төзергә кирәк.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Нәрсәнедер сортлау, аеру һәм чистарту эшендә кулланылган махсус машина яки җайланма. *[Ындыр табагында] биш электр моторы, ике зернопульт, ике сортировка --- эшләп тора.* Г.Галиев. *Биш ел эчендә Әхмәт белән икебезгә өч трактор, комбайн, «ГАЗ-53», яңа «КамАЗ», бөтен төр агрегатлар: чәчкеч, культиватор, агу сиптергеч, хәтта сортировка машинасына кадәр булдырдык.* А.Сабирова

3) Сортлау эше алып барыла торган бина, бүлек һ.б.ш. *Почтаның сортировка бүлмәсе зур түгел.* Татарстан яшьләре. --- *газета килмәгән очракта, редакцияне борчырга кирәкмидер, ә районнардагы почтаның «сортировка» дип аталган бүлекчәсе белән элемтәгә керергә һәм газетаны китерүләрен сорарга.* Безнең гәҗит

**СОРТИРО́ВКАЛАУ** *ф.* Сортлау, сортларга аеру, төрен төргә аеру

**Сортировкалап бетерү** Барысын да ахырга кадәр сортировкалау

**Сортировкалап тору** Даими рәвештә сортировкалау; хәзерге моментта сортировкалау белән мәшгуль булу

**Сортировкалый бару** Булган берен рәттән сортировкалау

**Сортировкалый башлау** Сортировкаларга тотыну

**СОРТЛАНУ** *ф. төш. юн.* Сортларга аерылу. *Сортланган каракүлләрне подвалга төшергәндә, мин бу кешене күргәли идем.* Ә.Еники

**Сортланып бетү** Барысы да ахырга кадәр сортлану

**СОРТЛАП** *рәв.* Сортларга аерып, сорты-сорты белән. *Күп колхозларда җитен сабагын озынлыгы, юанлыгы, өлгерүе, төсе буенча сортларга аермыйлар, ә бит сортлап тапшырганда, керем тагын да күбрәк алына, һәм ул өстәмә хезмәт чыгымнарын каплый.* Т.Нәҗмиев

**СОРТЛА́У** I *ф.* Сортларга аеру. *Ник дисәң, үзе белән меховойда тире сортлый торган хатыннар, Тәүгиз хәлен ишеткәннән соң, беравыздан, ул пленда, дип ышандырып әйткәннәр.* Х.Камалов

**Сортлап алу** Тиз генә сортлау

**Сортлап бетерү** Бөтенесен дә ахырга кадәр сортлау

**Сортлап кую** Сортларга аерган хәлгә китерү

**Сортлап тору** Сортлау эшен башкару. *Мехларны, күпме керсә дә, сортлап кына торабыз, цехта озак яткырмыйбыз, в общем, абзыйлар шәп эшлиләр.* Ә.Еники

**Сортлап чыгу** Һәммәсен аерым-аерым сортларга аеру

**Сортлый башлау** Сортларга тотыну

**СОРТЛА́У** II *и.* Сортларга аеру процессы, сортировка (*1 мәгъ.*). *Инде менә без – моңарчы мәче тиресе белән куян тиресен дә аера белмәгән яшь егетләр, яшь кызлар – шул мишәр дәдәйләрдән мех сортлауның нечкә серен өйрәнергә һәм тора-бара аларны акрынлап алыштырырга тиеш идек.* Ә.Еники

**СОРТЛЫ** *с. махс.* 1) Билгеле сыйфаттагы; билгеле бер сортка караган. *Игенче яңадан-яңа сортлы бодай-*

*лар үстерергә, астроном яңадан-яңа йолдызлар ачарга, укытучы яңадан-яңа талантлар табарга тырыша.* Ф.Яруллин. *Булган кешенең бөтен әйберсе югары сортлы була.* М.Маликова

2) Яхшы, сыйфатлы; югары сортка караган; *русчасы*: **сортовой**. *Мин киткәч, шул сортлы орлыкларга селекция уздыручы профессор ачтан үлә.* Х.Камалов. *Мин бит инде чәчүлек орлык белән сортлы ашлыкка кагыла алмыйм.* Ф.Садриев

3) *күч.* Нинди дә булса бер ягы, сыйфаты белән башкалардан аерылып торган. *Татар телендәге басмалар партия җитәкчелек иткән заманнарда икенче сортлыраклар рәтендә йөриләр иде.* Р.Фәйзуллин. *Безгә ул һәйбәт кешеләрне – беренче сортлы тәүфикъ ияләрен – югары квалификацияле белгечләрне әллә каян җибәреп җиткерә алмаячаклар.* Р.Вәлиев

**СОРТЛЫЛЫК** *и.* 1) Билгеле сортка караган булу, шул сорт дәрәҗәсе. *Халыкка автомат рәвештә түбән сортлылык мөһере суккан «автономия» дип аталуның янә бер әшәкелеге иде бу.* Т.Галиуллин

2) Сыйфатлылык, югары сортлы булу

**СОРТСЫЗ** *с.* Сыйфаты начар булган, түбән сортлы. *Сортсыз бәрәңгенең уңышы да артык күп булмады.* Ф.Сафиуллин. *Ләкин якын киләчәктә илдә ел саен сортсыз чималдан кимендә 400 мең тонна биоягулык эшләргә ниятлиләр.* Кызыл таң

**СОРЫ** *с.* Ак һәм кара төсләрнең кушылмасыннан торган; төтен, көл төсендәге. *Әмма мин аннан соң да, кара чәчләремне еллар соры көлгә әйләндереп беткән заманда да, чикләвекнең чәчкә атачагына ышандым.* М.Кәрим. *Картның соры күзләре, мин булыр дип өметләнәм, егетләр, дигән сыман иде.* А.Расих

**СОРЫК** *и. диал.* Себер татарларында тактадан эшләнгән дүрт ишкәкле зур көймә

**СОРЫКОРТ** *и.* 1) Бал кортларының үрчү чорында барлыкка килә, соңыннан оядан куыла һәм үлә торган ата корт; *русчасы:* **трутень**

2) *күч.* Кеше исәбенә яшәүче кеше, әрәмтамак. *Сорыкорт булып яшәргә ярамаганны аңларга вакыт инде.* Т.Гыйззәт. *Калдык-постык хезмәт хакына канәгать булып яши торган үшәннәр, сорыкортлар чит илләргә китеп куыш таба, нигез кора алмый.* Мәдәни җомга

**СОРЫЛАНУ** *ф.* Соры төскә керү, сорыга әйләнү. *Бу – Зөбәрҗәт күзләре бит. Ә нигә соң алар сорыландылар, саргайдылар?* Казан утлары

**Сорылана бару** Сорылыгы акрынлап арту, торган саен ныграк сорылану

**Сорылана төшү** Бераз сорылану; тагын да сорылану

**Сорыланып бетү** Тәмам сорылану

**Сорыланып җитү** Бөтенләй сорылану, соры төскә керү

**Сорыланып калу** Берәр сәбәп белән сорылану, нининдидер моменттан соң сорылану

**Сорыланып китү** Соңгы вакытта, кинәт сорылану. *«Жәл, жәл!» – дип тәкрарлады аптырап калган хирург: йөзе чытылган, битләре сорыланып киткән иде.* Х.Камалов

**СОРЫЛЫ** *с.* 1) Соры төс катнашкан; соры төсмерле. *Тирә-ягында, әллә нинди зәңгәрле, сорылы киемнәр киенеп, медальле күкрәкләрен киереп, --- бик мәһабәт тугыз кеше утыра.* Г.Ибраһимов

2) Катлаулы төсне белдергәндә: соры белән башка нининдидер төсләр аралашкан. *Күк йөзе өскә ишелергә торган сорылы-каралы яшен болытларына уралган.* Т.Кәримов

**СОРЫЛЫК** *и.* 1) Соры төс. *Һәм бу сорылыкны бетон биналарга сыланган ялтыравык пыялаларның җемелдәве дә җиңә алмый.* Безнең гәҗит

2) Караңгылык. *Ә Нургали алар көткән төндә түгел, әллә ниткән давыллы-хәвефле бер төн узганда, таң сорылыгы беленеп килгәндә тәрәзәгә чиртте.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Эчпошыргыч бертөслелек; активлык, рухи азык булмау күренеше. *Көнкүрешнең бертөрлелеге, ыгы-зыгысы, сорылыгы, корылыгы адәмне изә, күңелен төшерә.* Г.Хөсәенов. *Менә шушы сорылык пәрдәсен ертып ташлау, баш өстеңә кояш чыгару өчен, борылыш, үзгәреш, көтелмәгән яңалык кирәк.* Р.Низамиев

4) *күч.* Гадәтилек, әһәмиятсезлек, башкаларга охшаган булу, яңалыгы булмау. *Язучыларның исемнәрен төрлечә кабатлау аша, образның күпмәгънәлелегенә, сүз уйнатуга таянып, шагыйрь тәнкыйтьнең бер урында таптануын, сорылыгын шактый үткен күз алдына бастыра.* Т.Галиуллин

**СОС** *с.* 1) Төбәгән җиргә бик туры, төз тидерә торган. *Сос аучы*

2) Тиз төшенеп, җитез эшләүчән, булдыра ала торган. *Эшкә сос килен. Сос егет*

3) Тиз сизеп алучан. *Сос колак*

4) *диал.* Хәйләкәр, хәйләгә оста. *Шәхеснең тискәре сыйфатларын белдерә торган кушаматлар: Чәнечке (усал) Хәйри, Елан (мәкерле) Зәйтүнә, Мин-мин (мактанчык) Ислам, Сос (хәйләкәр) Вәли, Ошакчы (әләкче) Илдар, Зәнки (усал) Асия, Савыл (мактанчык) Саттар, Төмек (астыртын) Зифа һ.б.* Фән һәм тел

5) *диал.* Кәефсез, күңелсез

**СОСА** *и.* 1) Туку, киндер сугу станында шүрене кую һәм йөртү өчен, эче куыш итеп ясалган озынча агач җайланма. *Тәбәлдерек очкан җеп карнында чабак соса уйнап югала.* Ш.Маннур. *[Станок] кызу-кызу эшли. Сосаларны да кулга алып тору юк: автоматлар үзләре саплыйлар.* Азат хатын

2) Тегү машинасында теккәндә, җепле шүрене йөртә торган җайланма. *Сосага җеп чорналу*

**СОСИ́СКА** *и. фр.* Нечкә һәм озынча таякчык формасында эшләнгән, гадәттә пешереп ашала торган кечкенә колбаса. *Мине тыңлагач, энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән сосиска кебек бармакларын пумала башына батырып, бик озак уйланып утыргандай итте.* Т.Галиуллин

**СОСКЫ** *и.* Бөртекле яки вак-вак кисәкле нәрсәләрне сосып, җыеп ала торган көрәкчек сыман корал. *Тугызлар тирәсендәге малай зур тимер көрәк тоткан, алты яшьләрдәге кызыкай кыска саплы соскы алган.* М.Кәрим. *[Шәмсулла:] Син дә итәгеңне-чабуыңны*

*алдан җый, большевикларга бер соскы икмәгең дә китәрлек булмасын.* Г.Галиев

**СОСКЫЧ** *и.* 1) Сосып, чумырып ала торган зур чүмеч сыман корал. *Невод салу тукталгач, алар берничә көн лабазда эшләделәр: тозланган селёдкаларны озын саплы соскычлар белән чаннардан сөзеп чыгардылар.* Ш.Камал

2) *диал. к.* **соскы**. *Карлыгач белән Сөмбел бер башын элгән зур тимер кисмәккә чиләкләр һәм соскычлар белән, ашыга-ашыга, бодай тутыралар.* Г.Бәширов

**СОСЛА** *и. рус* Йорт сырасы, куас һ.б.ш.ны ясау өчен, салатны суда җебетеп әчетергә куелган ярымфабрикат; *русчасы:* **сусло**. *Күршеләр тәкә суеп, сосла кайнатып, җыен бәйрәменә хәзерләнгәндә, безнең казанга атналар буе итле аш керми башлады.* Г.Бәширов. *Элекке заманнарда шулай ук сыек һәм куе сосла, буза, бал да әзерләгәннәр.* Ю.Әхмәтҗанов

**СОСЛАН** *и. рус* Киптерү өчен, басуда өеп куелган ашлык көлтәләреннән торган чүмәлә. *Көннең-көнозын кояш кыздырган калкулык битендә өй урыны кадәр генә урылган җир һәм аның уртасында бер сослан күренде.* Н.Фәттах. *Уйсу җирләрдә, сослан күләгәләрендә төш турында да кырпак була.* Л.Ихсанова

**СОСЛАНУ** *ф.* Төбәгән җиргә тидерүдә бик остару, соска әйләнү

**Сослана бару** Торган саен ныграк сослану

**Сосланып китү** Соңгы арада сослану

**СОСЛО́ВИЕ** *и. рус тар.* Капитализмга кадәрге җәмгыятьтә барлыкка килгән, хокуклары-бурычлары закон тарафыннан билгеләнгән һәм нәселдән нәселгә күчә килгән иҗтимагый төркем, сыйнфый катлам. *Муллалар, берберсенә тыгыз бәйләнгән булып, ныклы бер катлау – сословие тәшкил иткәннәр.* И.Нуруллин. *Аңлый да алмассың, сез бит бүтән сословие кешеләре.* Ә.Әминев

**СОСЛО́ВИЕЛЕ** *с. тар.* 1) Сословиеләре булган, сословиеләрдән торган, сословиеләргә бүленгән. *Сословиеле җәмгыять. Сословиеле дәүләт*

2) *к.* **сословиечел** (*1 мәгъ.*). *Сословиеле оешма*

**СОСЛО́ВИЕЧЕЛ** *с. тар.* 1) Сословиеләргә бүленгән җәмгыятькә хас; сословиеләргә бүлеп башкарыла торган. *Сословиечел уку йортлары. Сословиечел сайлау системасы*

2) Югары сословиеләр, шуларның вәкилләре катнашында башкарыла торган. *Сословиечел дәүләт идарәсе*

3) Бүтән сословиеләргә түбәнсетеп карауга нигезләнгән, югары сословиеләргә хас. *Шагыйрьчә, чын кешелек хисе иҗтимагый-сословиечел хорафатларны белми, бәлки, киресенчә, аларны баштүбән әйләндереп салырга сәләтле.* Н.Хисамов

**СОСЛО́ВИЕЧЕЛЕК** *и.* 1) Сословиеләргә бүленгән булу; сословиеле иҗтимагый система

2) Билгеле сословиегә хас карашлар; үз сословиесе күзлегеннән чыгып фикер йөртү үзлеге. *Аныңча [М.Фәйзи] «күңелле тормыш» булдыру өчен --- ярлы белән бай арасындагы сословиечелекне бетерү, дини хорафатлардан арыну, тырышып эшләү кирәк.* Татар әдәбияты тарихы

**СОСЛЫК** *и.* Сос булу үзлеге. *Малайлар, минем бу сослыкны (төбәп ыргыткан җиргә бик туры тидерүемне) хуплап, үзара шаркылдашырга тотындылар.* Ф.Хөсни

**СОСЛЫМ** *и. диал. к.* **сослан**. *--- Яшьлектә кизәнгән Зур эшләрем бетмәгән... Узган гомерем – сослымнарга куелмаган көлтәләр.* Г.Мөхәммәтшин

**СОСТАВ** *и. рус* 1) Бербөтенне тәшкил иткән өлешләрнең, предмет, кеше һ.б.ш.ларның бөтенесе. *Спектакльдә бөтен состав диярлек алышынып бетте.* Н.Ихсанова. *Югыйсә состав та әлләни үзгәрмәде, баш тренер да шул, ә уен юк.* Татарстан яшьләре. *Татар теленең сүзлек составы*

2) Берәр учреждение, предприятие, хәрби частьны тәшкил иткән кешеләрнең барлыгы. *Полкның моннан элекке составы, вак командаларга бүләнеп, сугышка озатылды.* К.Нәҗми. *Аннан политбюро составын сорадылар, аннан --- иң даһи юлбашчының биш төрле хезмәт урынын санап чыктым.* М.Мәһдиев

3) Һөнәре, эш урыны, хезмәт вазифасының үзенчәлеге белән аерылып торган бер категория тәшкил иткән кешеләр. *Ул бик озак уйланып торды, аннары рядовой составның исемлеген сорады.* Г.Әпсәләмов. *Рафис --- ул чактагы колхоз рәисе Харис Галимуллин һәм башка җитәкче состав – белгечләр белән берлектә җиң сызганып эшкә кереште.* Татарстан яшьләре

4) Берәр химик катнашмага кергән матдәләр, гомумән берәр нәрсәнең эчтәлеген тәшкил иткән берәмлекләр. *Плитәләрнең тыгызлыгы катнашманың составына һәм тыгызлау ысулына бәйле.* Р.Шакирҗанов. *Комның составы аның минераль составы, бөртек составы һәм зыянлы кушылмалар микъдары белән билгеләнә.* Төзү материаллары

5) Бергә беркетеп тезелгән тимер юл вагоннары; поезд. *Буш вагоннардан теркәлгән бик озын состав иде бу.* Н.Фәттах. *Ул арада поезд соңгы тапкыр ачы итеп кычкыртып җибәрде, ишекләр ябылды, состав көзән җыергандай тартышып куйды һәм алга ыргылды.* Ф.Бәйрәмова

6) Төрле элементлардан, матдәләрдән торган катнашма, кушылма, сыеклык. *Иртән, студентлар килгәнче, карт ишек тоткаларын һәркөн үзе генә белгән состав белән сөртә, сукно белән ялтырата.* М.Мәһдиев. *Корылмаларның ачык өлешләре (цоколь, кәрниз, багана) саклансын өчен, аларны су агып төшәрлек итәләр яки өслеккә тыгызлагыч составлар сөртәләр.* Р.Шакир

7) *лингв.* Җөмләнең баш кисәге һәм турыдан-туры шуңа бәйле кисәкләр. *Бер составлы җөмләгә икенче состав өстәп булмый.* М.Зәкиев. *Җөмләдә баш кисәкләр икәү булса, ягъни ия дә, хәбәр дә булса, алар барлык башка кисәкләрне үзләренә буйсындырып (җыйнак җөмләләр үзләре генә), ике состав барлыкка китерәләр.* Фән һәм тел

**СОСУ** *ф.* 1) Нинди дә булса сыек яки сибелүчән нәрсәне зур савыттан берәр кечерәк нәрсә белән чумырып алу. *Җиңгәчәсе зур агач табак белән аш сосып китерде.* Ә.Еники. *Хәдичә*

*әби ничә сәгатьтән бирле ут өстендә торкан ашын, сосып, кызы алдына куйды.* Л.Ихсанова

2) *күч.* Кабаланып, әдәпсез рәвештә, күп итеп ашау. *Шунысы яхшы: ире нинди генә махмырдан булмасын, шөкер, бик яхшы ашый. Хәтта андый чакларда, кемдер әйтмешли, соса гына!* Ә.Сафиуллин. *Ипи телемен кул яссуы калынлыгы кисә, вак бәлешләрне бер кабуда йота, ашны, ботканы чүмеч хәтле агач кашык белән соса иде.* Д.Салихов

3) *күч.* Законсыз рәвештә үзенеке итү, үзләштерү, күпләп урлау. *Безнең шәһәр байлары Мәскәү малын сосалар. Корзинкалап сыра эчкәч, чыдый алмый косалар.* Ш.Мөхәммәдев. *Ул келәтләргә сугыш кулы да кереп капшады. Кергән саен состы гына.* Н.Дәүли

4) *күч.* Сугу, берәр нәрсә белән кискен ору, бәрү. *Кәрәмәтулла хәзрәт, камыш таягын киң селтәнеп, фәскә шундый китереп состы: --- фәс арба тәгәрмәче астында калган калай банка кебек янчелеп килде.* Г.Гобәй. *Бусагадан атлавым белән, әти ачуын миңа күчерде. Әйләндереп торып берне состы да шундый хөкем чыгарды.* Совет әдәбияты

**Соса башлау** Сосарга керешү. *Бабай туз кашык белән җайлап кына кортларны тубалга соса башлый.* А.Алиш. *Алъяпкычлы солдат, табуреткага басып, биек тәгәрмәчләр өстендәге казаннан озын саплы чүмеч белән безнең котелокларга аш соса башлады.* Ә.Еники

**Соса бирү** Бернигә карамый сосуны дәвам итү

**Сосып алу** Бераз, бер ара сосу; бер мәртәбә сосу. *Сүс чыбыркы белән юри генә, искәртер өчен генә берәрне сосып та алгач, аның үшән биясе әкрен генә су аркылы чыгып китә.* Ш.Маннур

**Сосып бетерү** Барысын да сосу; сосу эшен тәмам итү

**Сосып кую** Алдан сосу. *Атасы, мунча яктырган идем, өлгергән. Аннан, аш та сосып куелган ---.* Т.Гыйззәт. *Өстәл уртасында табакка сосып куелган бәрәңгеле кайнар ит пар бөркеп утыра иде.* Д.Бүләков

**Сосып тору** Шактый вакыт дәвамында сосу; әле, күз алдында сосу. *[Фатыйма иренә:] Читтән килгән алма байлары кыйбатрак бирүчән булалар, сатма шул комсыз шайтанга, болай да авылның бөтен байлыгын сосып тора инде ул.* И.Гази

**Сосып чыгу** Рәттән, тәртибе белән, башыннан ахырына кадәр сосу. *Сәкинә җиңгәсе кунакларның тәлинкәләренә пилмән сосып чыкты.* Ә.Еники

**СО́ТКА** *и. рус сөйл. к.* **сотый**. *Ишегалдында кемнәрдер йөри, үлчәгеч таяк тотканнар, бер сотка җирең артык икән, шуны кисеп, киртәңне күчерттерәләр.* М.Мәһдиев

**СО́ТНИК** *и. рус тар.* 1) Төрле чорларда төрле илләрнең гаскәрләрендә йөз кешелек гаскәри берәмлек башлыгы

2) 1917 елга кадәр Россиядә казак гаскәренең җәяүле гаскәрдә поручик чинына туры килгән офицер чины һәм шул чиндагы кеше. *«Ваше благородие» – казак разведкасының начальнигы – сотник өстәлдәге тулы чәшкә самогонны эчеп җибәрде.* Ш.Усманов

3) *к.* **сотский** (*2 мәгъ.*). *Шул турыда бүген староста, сотниклар киңәшкәннәр дә җиде җиргә каравыл куярга булганнар.* Т.Гыйззәт. *--- дәүләт буйсындырылган халыклар белән идарә итү, алардан салымнар җыю, рекрут алу һ.б. эшләрне оештыруда җирле халык арасыннан чыккан күпсанлы староста, сотник, старшина, тылмачлар кебек кешеләр ярдәменә мохтаҗ.* М.Гайнетдинов

**СО́ТНЯ** *и. рус тар.* 1) 1917 елга кадәр Россиядә һәм башка илләрдә төрле чорда һөнәрче, сәүдәгәр һ.б.ш.ны берләштергән, баштарак йөз кешедән торган оешма

2) 1917 елга кадәр Россия һәм кайбер башка ил армияләрендә йөз кешедән торган гаскәри подразделение. *[Данила:] Гриша, син хәзер үк станциягә чап, бер сотня казак җитә, диген. Таң алдында бер һөҗүм белән бетерербез.* Ш.Усманов

**СО́ТСКИЙ** *и. рус тар.* 1) XVI–XVIII гасырларда Россиядә төрле сыйнфый катлау, кала бистәсе, һөнәри берлек һ.б.ш.лардан сайланган вәкил; йөз вәкиле

2) Крестьяннар арасыннан, нинди дә булса җәмәгать эшләрен яисә полиция вазифасын башкару өчен, гадәттә йөз йорттан сайланып куелган староста. *Вахитны алырга киткән сотский берничә минут эчендә кире кайтты.* М.Гафури. *[Исправник:] Менә нәрсә, сотский. Мин бүген китмим, монда гына кунам.* Т.Гыйззәт

**СО́ТЫЙ** *и. рус* 1) Гектарның йөздән бер өлешенә тигез җир үлчәү берәмлеге; ар. *Кеше киленнәре --- ун-унике сотый урганда, Васфикамал арышының иң куе җиреннән егерме өч сотый урып килде.* М.Мәһдиев. *[Хөсәен:] --- Тотным да, нәкъ егерме биш сотыйга гына калдырып, рәшәткәмне күчердем дә куйдым.* Р.Төхфәтуллин

2) Элек колхозда: хезмәт көненең йөздән бер өлеше. *Без аңа укыган вакытында [көнгә] 75 сотый хезмәт көне бирдек.* Ә.Айдар

**СО́УС** *и. фр.* 1) Өзер ашамлык янына бирелә торган сыек аш тәмләткеч. *Зур куна өстенә тәлинкә белән тәбикмәк, соуслар, салат тезгән официант егетләр искиткеч зур тизлек белән агачлар арасында йөгерешеп йөриләр, безне сыйлыйлар.* М.Мәһдиев. *Гадәттә ул кунакханәдә яки ресторанда менә мондый заказ ясый торган булган: сыер ите, бозау ите белән шпинат, бәрәңге, ак соус белән балык, сарык итеннән кәтлит ---.* М.Хәмзина

2) *күч.* Эшнең асылын аңларга комачаулаган нәрсә, үзгәртеп күрсәтү өчен, махсус тудырылган тышкы күренеш

**СО́УСЛЫ** *с.* Соус катнаштырылган, соус салынган. *Соуслы гарнир*

**СОФА** *и. фр.* Утыру-яту өчен билгеләнгән артлы һәм янлы киң тәбәнәк диван. *Түрдәрәк киң агач софа, икенче якта ишектән керүгә үк аш өстәле, шуның янында ук китап киштәсе: Достоевский һәм Писемский томнары тезелеп киткән.* Х.Ибраһим. *Өйдә рәтле мебель дә, җиһаз да юк. Иске бер софа да Сталин заманында эшләнгән имән өстәл һәм дүрт урындык.* Р.Сәгъди

**СОФИЗМ** *и. гр. кит.* Ялган раслауны дөрес итеп күрсәтү өчен файдаланылган, формаль яктан дөрес шикелле

күренгән, әмма эчке логик хатасы булган фикри нәтиҗә; логик хәйлә

**СОФИСТ** *и. гр. кит.* 1) Борынгы Грециядә башта акыл иясе, белгеч; соңрак түләүле фәлсәфә, матур сөйләм укытучысы

2) Безнең эрага кадәр V–IV гасырларда борынгы Грециядә этика, сәясәт, танып белү теориясенә керткән өлешләре һәм сүз осталыгы белән дан тоткан мәгърифәтчеләр төркеме вәкиле

3) Ялгыш фикерләрен, гипотезаларын раслау өчен, софизмнарга нигезләнеп эш итүче

**СОФИ́СТИК** *с. кит.* Софизмга нигезләнгән, шуны файдалана торган. *Софистик бәхәсләр. Софистик алым*

**СОФИ́СТИКА** *и. гр. кит.* Софизмга нигезләнеп фикер йөртү, софистик алымнардан файдаланып, үз файдасына субъектив нәтиҗәгә килү

**СОФО́РА** *и. лат. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан каурыйсыман яфраклы, ак, сары, ал чәчәк ата торган, яфрагын коючан яки мәңгеяшел агач, куак, үлән. *Софора составында агулы алкалоидлар бар.* Биология

**СОХАРИ** *и рус* Киптерелгән икмәк. *[Яшьләр] Кайсы йомырка белән ипи кисәге капкалый, кайсы кипкән балык суыра, сохари кимерә.* Ә.Хәсәнов. *Безнең тешләр – Колымаларда сохари кимереп, колхозларда зирек каерысы чәйнәп чарланган тешләр, дим.* Ф.Яруллин

**СОХБӘТ** *и. гар. кит.* 1) Утырышу, берәү белән әңгәмә корып сөйләшеп утыру; әңгәмә. *Нәфес бер гүзәл белән дә сохбәт итүне теләр.* З.Һади. *Казый Әбүшәрифкә әйтте: – Әй борадәр, иртәгә кичкә бу бакчага кил дә әлбәттә мәне күр. Минем синең илә һәрзаман сохбәт итәсем киләдер, – диде.* Ф.Хәмид

2) Мөгаллим белән шәкертнең рухи әңгәмәсе, бәйләнеше

3) Суфичылыкта шәех һәм мөршидләрнең нәсыйхәтләрен һәм вәгазьләрен тыңлау

**СОЦ-** 1) Кушма сүзләрдә «социалистик» мәгънәсендәге беренче кисәк

2) Кушма сүзләрдә «социаль» мәгънәсендәге беренче кисәк. *Ә авыл җирендә соципотека ярдәме белән йорт салучыларның балалары туса, алар йортның 21,2 квадрат метры өчен түләмәячәкләр.* Татарстан яшьләре

**СОЦИАЛ-** Парлы сүзләрдә «социализм» мәгънәсендәге беренче кисәк. *Социал-патриот, социал-шовинист*

**СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТ** *и. нем.* 1) Социал-демократия тарафдары. *Хәдичәнең ире Россия империясендә --- яңа тәртипләр урнаштырырга йөрүче революционер социал-демократ булып чыкты.* А.Расих. *Бер-бер артлы сораулар яудырырга кереште Солтангалиев: – Фиркалеме үзе? Тоткан мәсләге ни? Социал-демократ түгелдер ич?..* Р.Мөхәммәдиев

2) Социал-демократлар партиясе әгъзасы. *– Менә әле яңа гына социал-демократлар партиясенә кердем, – диде Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев. *Германиянең тышкы эшләр министры, социал-демократ Франк-Вальтер Штайнмаер бераз йомшаграк караш та тора.* А.Гыйльми

**СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТИЗМ** *и. лат.-гр.* Социал-демократия идеологиясе – тәгълиматы һәм тактикасы

**СОЦИАЛ-ДЕМОКРА́ТИК** *с.* Социал-демократиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган, шуңа нигезләнгән. *Социал-демократик партия. Социал-демократик мөнәсәбәтләр*

**СОЦИАЛ-ДЕМОКРА́ТИЯ** *и. лат.-гр.* 1) Социализм кысаларында барлыкка килгән, бердәмлек, ирек һәм социаль гаделлек урнаштыру максаты белән, капитализмны камилләштерүне яклаган сәясәт һәм идеологик-сәяси юнәлеш. *Халявин социал-демократия хәрәкәтенең үз алдына куйган теләкләре турындагы главага күчте.* К.Нәҗми

2) Социалистик фиркаләрнең гомуми исеме. *Думаны да куалар, эш ташлауларны да басалар, социал-демократия фракциясен кулга алып, хөкемгә бирәләр.* Г.Ибраһимов

3) Социал-демократлар. *Рус социал-демократиясе*

**СОЦИАЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Социализацияләү процессы һәм нәтиҗәсе. *Докладыбызның темасы «Бүгенге Русиядә яшьләрнең социализация проблемасы» иде.* Татарстан яшьләре

**СОЦИАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Җәмгыятьтә яшәү, уку, һөнәр алу процессында шул җәмгыятьтә кабул ителгән мөнәсәбәтләр, иҗтимагый элемтәләр, аралашу һ.б.ш. тәҗрибәне үзләштерү

**Социализацияли башлау** Социализацияләү эшенә керешү

**Социализацияләп җиткерү** Тиешенчә социализацияләү

**СОЦИАЛИЗМ** *и. фр.* 1) Социаль гаделлек, тигез хокуклылык һәм ирекне идеал һәм төп максат итеп куйган тәгълимат. *Чанышев --- Казан гарнизонында да социализм идеяләренең популярлык казана баруын искәртеп узды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Шундый принципларга нигезләнгән җәмгыять һәм дәүләт строе. *Реакция керү белән, эсер Разия, Фәхри, Йосыфҗан, социализмны, революцияне ачыктан-ачык таптап, --- капитализм сафына күчәләр.* Г.Ибраһимов. *Илнең кинәйтелгән темп белән социализм төзелешенә керешүе Такташ иҗатында да борылыш ясады.* Г.Нигъмәти

**СОЦИАЛИСТ** *и. рус тар.* 1) Социализм тарафдары. *Мин үзем дә социалист кеше, ләкин большевиклар белән рәхимсез көрәш вакытында сөйләнеп тору зарарлы.* Т.Гыйззәт. *[Петров:] Ярдәм итәрләр менә! Әгәр эш башына тагын бер социалист менеп утырса, тагын шул сүз боткасы башланыр.* Ш.Усманов

2) Социалистик партия әгъзасы. *Янәшәсендә дәшми-нитми генә утырган Мулланур Вахитов сәхнәгә менеп басты. – Мөселман социалистлары комитетыннан, большевик Мулланур Вахитов, – диде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә менә инде урамга яшь социалистлар, католиклар берләшеп чыкса, җитәкче әһелләр борчыла башлый.* Т.Галиуллин

**СОЦИАЛИ́СТИК** *с.* 1) Социализм принципларына нигезләнгән. *Фашистик Алманиягә каршы көрәштә оешкан Атлантик берләшмә Икенче бөтендөнья сугышыннан соң СССР җитәкчелегендәге социалистик лагерь белән ярышта тагын да ныгый төште.* Р.Сафин. *М.Фәйзи Бөек Октябрь социалистик революциясен «Галиябану»*

*драмасын язып каршылый.* Татар әдәбияты тарихы

2) Социализм идеяләре белән сугарылган. *Яңа идеологияне «пролетар идеология» дип тә, «социалистик» яки «коммунистик идеология» дип тә атыйлар, «совет идеологиясе» дип әйтү дә бар.* А.Әхмәдуллин. *30–50 нче еллар әдәбиятының күп үрнәкләре социалистик реализм таләпләренә җавап бирә.* Т.Галиуллин. *Социалистик тәрбия*

3) Социализм строена хас. *Социалистик җитештерү мөнәсәбәтләре. Социалистик тәртипләр урнаштыру*

4) Социал-демократиягә мөнәсәбәтле. *Социалистик партия*

**СОЦИАЛ-ШОВИНИЗМ** *и. лат-фр.* Халыкара эшче хәрәкәт эчендә Беренче бөтендөнья сугышы чорында барлыкка килгән, үз хөкүмәтләренең хәрби агрессия сәясәтен хуплаган агым

**СОЦИАЛ-ШОВИНИСТ** *и. лат-фр.* Социал-шовинизм тарафдары

**СОЦИАЛЬ** *с.* 1) Җәмгыятькә мөнәсәбәтле, җәмгыятьтәге кешеләрнең тормышына бәйле, иҗтимагый. *Габдулланың үткен күзе һәм сизгер күңеле авылның социаль каршылыкларына да игътибар итми калмаган, дип уйларга кирәк.* И.Нуруллин. *Озак гасырлар дәвамында мәхәббәт лирикасының традицион төре булып исәпләнгән газәл жанры Тукайда тирән социаль эчтәлек белән баетылды.* Р.Ганиева

2) Җәмгыять вазифасына караган, аның тарафыннан башкарыла торган. *Бу – [«Хуҗа Насретдин» комедиясе] халыкның үзе сораган постановкасы иде, --- һәм күкрәк тутырып көләсе килгән халыкның социаль заказы иде.* А.Әхмәт. *Алар безгә, милләт, тел аермалыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап, интернациональ әдәбият тудырырга социаль заказ бирделәр.* Һ.Такташ

**СОЦИАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф. к.* **социализацияләү**. *Егет-кызларыбызны яшьтән үк социальләштерү механизмнарын үстерергә, аларның көч-куәтен ачарга һәм иҗади юлга юнәлтергә кирәк.* Р.Миңнеханов. *Бүген педагогикада америка социологы Толкотт Парсонс керткән «социальләшү» дигән яңа төшенчә кулланыла башлады.* Фән һәм тел

**СОЦИО́ЛОГ** *и. рус* Социология белгече. *Социолог буларак Энҗе андый категорияләргә керүчеләрне дә белә.* М.Мәһдиев. *Социологлар фикеренчә, утызның өске ягына чыккан ир-ат, буйдак тормышның «түмән» татыгач, --- гаилә мәшәкатьләрен җилкәсенә салу мәсьәләләрендә шикләнә...* Т.Галиуллин

**СОЦИОЛОГИЗМ** *и. лат.-гр.* 1) Фәнни тикшеренүдә җәмгыятьтәге теләсә кайсы рухи яки материаль күренешне социаль факторларга кайтарып калдырудан гыйбарәт, артык гадиләштереп, вульгарлаштырып тикшерү алымы

2) *әд.* XX гасырның 20 нче елларында әдәбият белемендә әдәби процессны, язучы ролен артык примитив аңлаткан агым. *Нигъмәти – илдә пролетариат диктатурасы һәм идеологиясе хөкем сөргән, әдәбият-сәнгать өлкәсендә вульгар социологизм карашлары өстенлек иткән чорда яшәгән шәхес.* Әдипләребез

**СОЦИОЛО́ГИК** *с.* Социологиягә карый торган, шуны чагылдыра торган. *Социологик тикшеренүләр шуны раслый: гәҗитләрнең 32–36 процент мәйданы сәяси язмаларга бирелә.* Р.Фәйзуллин. *Социологик сорашулар барышында халыкның 85 проценты, начар туклану – фәкыйрьлекнең бер билгесе, дип белдергән.* Татарстан яшьләре

**СОЦИОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Җәмгыятьнең үсеш һәм яшәү закончалыкларын бөтен бер система итеп өйрәнә торган фән. *Мине дә, үз эшемне ташлап, социология белән шөгыльләнергә кодалыйсызмы?* Р.Вәлиев. *[Г.Ибраһимов] Вак хикәяләре, гыйльми язмалары, тарих һәм социология, әдәбият белеменә караган хезмәтләре белән таныла.* Д.Заһидуллина

**СОЧИНЕ́НИЕ** *и. рус пед.* Тәкъдим ителгән темага укучының үз сүзләре белән язган мөстәкыйль эше; мәктәптәге язма эшләрнең бер төре; инша. *Үзем сочинение язам, Тургеневның Базаровын мактыйм, үзем, имтиханнан чыгу белән, Арча кызына җәйлап кына сүз кату планын корам.* А.Хәсәнов. *Мәктәптә ирекле сочинение вакытында да Фәнияр шул теманы сайлаган иде бит.* Ф.Яруллин

**СОЮЗ** *и. рус* 1) Сыйныфлар, иҗтимагый төркемнәр яки аерым кешеләр бергәлеге. *Төрк – «туганнар, кардәшләр союзы, берлек, кодрәт, көч» дигән сүз.* Р.Әхмәтьянов

2) Уртак максатларга ирешү өчен, дәүләтләр, партияләр һ.б.ш.лар арасында төзелгән килешү, берләшмә; коалиция. *Яңадан-яңа җирләргә күчәкүчә, һун кабиләләре үзәк Европага барып чыгалар, күпсанлы герман кабиләләрен буйсындырып, алар белән союз төзиләр.* Р.Әхмәтьянов. *Антифашистик союз*

3) Бер югары хакимияткә буйсынган аерым дәүләтләр, җирләр һ.б. берләшмәсе. *Анда [стендта] М.Җәлилгә сугышчан батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме һәм иҗат батырлыгы өчен Ленин исемендәге дәүләт бүләге бирелгәнлеге бәян ителә ---.* Л.Хәмидуллин. *Ул елны Советлар Союзы Гимны сүзләрен һәм музыкасын язарга бәйге игълан ителгән була.* М.Галиев. *Европа Союзы*

4) Иҗтимагый оешма, берлек. *Ләкин бер фикеремнән кире кайтмыйм: әгәр Язучылар союзы шәхесне кыса икән, ул кирәкми.* Т.Миңнуллин

5) Бергәлек, бердәмлек, бер сүздә булу, татулык. *Мондый ач күзле байлар илә тартышмак өчен, приказчиклар вә хезмәтчеләр, үзләре берләшеп, союзлар ясамак тиештер. «Берлектә тереклек» дигән борынгылар сүзен һич онытырга ярамый.* Ш.Мөхәммәдев. *Гайшәтти китап тыңларга бик ярата, үзе укый белми, менә шундый бер «союз»: әнидән китап. --- тын алмыйча тыңлаучысы – Гайшәтти.* М.Мәһдиев

**СОЮ́ЗАРА** *с.* Берничә союзга караган. *Союзара элемтәләр урнаштыру*

**СОЮЗДАШ** *с.* Бер үк союзда (*1–3 мәгъ.*) торучы, союз элемтәләре белән бәйле булган. *СССР таркалгач, союздаш республикалар мөстәкыйль дәүләткә әйләнделәр.* Т.Миңнуллин. *Большевиклар үзләренә союздаш булган эсерлар партиясенең 1918 елның июнь аенда җыелган съездын да куып таратталар.* З.Зәйнуллин

**СОЮЗДАШЛЫК** *и.* Билгеле союз әгъзасы статусы; бер үк союзда булу.

*Бездә яшәүче күп кенә руслар (бу – депутатлар арасында да шулай) союздашлык статусы мәсьәләсенә сагаеп карый.* М.Галиев

**СОЮ́ЗНИК** *и. рус* 1) Теләктәш, тарафдар, кем беләндер бер булып, шуның яклы эш итүче; бер союзга (*2 мәгъ.*) караган. *Зәкәрҗан Союзниклар армиясе офицерлары кия торган яшькелт соры кыйммәтле шинельләр киеп кайтты.* М.Мәһдиев. *Гомумән чукынмыйча калган йомышлылар һәм морзалар һәр яктан кысылалар, рус дворян сыйныфы аларны союзник итеп алмый.* С.Алишев

2) *күч.* Кемгәдер булышлык итә, ярдәм күрсәтә торган нәрсә. *Нигә, нигә суык патша һәрчак Рәсәй җәзачыларының союзнигы булды икән?..* А.Гыйләҗев

**СО́Я** *и. кыт. бот.* 1) Күбәләкчәчәклеләр семьялыгыннан бөртеге азык буларак һәм техник максатларда кулланыла торган, күренеше фасольгә охшаш берьеллык үлән үсемлек; кытай борчагы. *Бары тик 1990 елда соя онын азык продуклары алу өчен куллананалар.* Биология. *Тулы кыйммәтле яшел азык алу өчен, гадәттә соя, борчак, чәчүлек карга борчагы белән кушып чәчәләр ---.* Агулы үсемлекләр

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы орлыгы. *Японнар, киресенчә, аксымга бай соя продуктлары, дөге, диңгез суүсемнәре белән туклана.* Матур буласың килсә

**СӨАЛЬ** *и. гар. иск. к.* **сорау** II (*1 мәгъ.*). *Минем сөальләремә каршы берәр генә җөмләле өзек-өзек җаваплар бирде [Г.Тукаев].* Ф.Әмирхан. *Хәзрәт, түгәрәк сакалын учлап, елмая төште ---. Аннары тагын сөаль бирде: «Син ислам дине белән танышмыни?»* Г.Бәширов

**СӨБХА́НАЛЛА** *ы. гар.* **1.** 1) Гаҗәпләнү, соклану, хуплау хисләрен белдерә. *[Хәдичә Ханнанга:] Сөбханалла, сезгә ни булды, әллә авырыйсызмы?* А.Таһиров. *Янәшәдәгеләр, бу изге гамәлне хуплап, төрлечә куанычларын белдерделәр. Төрле яктан «Бәрәкалла!», «Афәрин!», «Сөбханалла!» дигән сүзләр ишетелде.* Г.Бәширов. *[Гайнетдин:] Сөбханалла! Сүзләрең фәрештәнең амин дигән чагына туры килсен! Киттем гөбернәтергә!* И.Юзеев

2) Сокланып караганда яки мактаганда әйтелә, еш кына «күз тимәсен» дигән мәгънәне белдерә. – *Сөбханалла, – ди Сөббух, әллә көлеп, әллә инде чынлап. – Син көннән-көн матураясың.* --- И.Салахов. *Һе-һе, нинди зур кызың бар икән, сөбханалла!* М.Галәү. *Баштарак ул минем битләремне ачып йөртергә рөхсәт итә иде, соңыннан: «Сөбханалла, бигрәк чибәрләнеп киләсең ---», – дип, битне каплатып йөртә башлады.* Ф.Яруллин

3) Берәр нәрсәгә гаҗәпләнеп, канәгатьсезлек белдереп, нәрсәдәндер кинәт куркып әйтелә торган сүз, «Ходай ихтыяры белән» дигәнрәк мәгънәгә ишарәли. *Харап эшләр, сөбханалла, сөбханалла!* К.Тинчурин. *Иркә солдат, уйлый-уйлый, үзе дә сизми, базга килеп төште. – Сөбханалла!* Һ.Такташ

**2.** *рәв. мәгъ.* Матур, яхшы. *Ахырда итләч ирене белән елмайды да: «Үзең болай, кем, сөбханалла күренәсең», – дип, соклануын белдерде [хәзрәт].* Х.Мәхмүт

**СӨЕК** *и. диал.* **1.** 1) Кемгә дә булса карата наз; шатлык. *Сөйгәнгә сөек, көйгәнгә көек.* Мәкаль

2) Сөюле мөгамәлә, аеруча якын итү. *Сөек белән дәшү*

**2.** *с. мәгъ. к.* **сөекле** (*1 мәгъ.*). *Кыз күңеле юка пыяладай, Бармак чиртсәң – шундук уала, Уртәмә син берүк Илсөярне, Әнкәсенә сөек ул бала.* Ф.Яхин

**СӨЕКЛЕ** *с. шигъ.* **1.** Аеруча якын, кадерле, яратыла торган. *Җегет асыл киемнәрен киде, сөекле толпары Байчобарны иярләде, камчыны билгә такты да, ил-күз тынгач, ат җилдереп, Алтын Күлгә, Сарсымбай җәйләвенә килде.* Г.Ибраһимов. *Син сөекле эштә җиңсәң генә, Җиңсәң генә бары – кеше син!..* М.Җәлил

**2.** *и. мәгъ.*1) Яраткан кеше; сөйгән яр. *Тагын яз җитте, торналар туе башланды. Димәк, Фатыйманың да сөеклесе килергә күп вакыт калмаган.* З.Кадыйрова. *Әбү-Талип та Мөхәммәдне бүтән Шам ягына сәфәргә алмады. Васыятен исеннән чыгармады, сөеклесен күз карасыдай саклады.* Ф.Яхин

2) **сөеклем** *тарт. форм.* Сөеп, үз итеп, иркәләп атау, эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *Әмма исемә төшкәч, хәзер дә оялып куям – аны күтәреп кергәндә, мин аңа нинди генә иркә сүзләр әйтмәдем: җаным, дидем, бәгырем, дидем, сөеклем минем, матурым минем, дидем...* А.Шамов. *Әгәр дә, сөеклем, синең белән кавышмаган булсак, шушы сазлыкта батып каласы идем бит!* Ф.Яхин

**СӨЕЛҮ** *ф. төш. юн.* **сөю**. *Без икебез ике кеше: үзебезчә сөенәбез, үзебезчә яратабыз, үзебезчә сөеләбез.* Р.Миңнуллин. *Безнең мәхәббәткә сусап зарыккан җаннарыбыз назга, сөю һәм сөелүгә мохтаҗ, без шул бөек хискә омтылабыз.* Л.Шагыйрьҗан

**СӨЕНДЕРҮ** *ф.* Сөенүгә сәбәпче булу, шатландыру, күтәренке кәеф өстәү. *Кил, сөендер, дилбәрем, кил, шат булыйк, Кил, көлик, сөеник, сәгадәтләр телик.* С.Сүнчәләй. *Тукта, Әхмәт абзыйларга әйтеп сөендерим әле.* Т.Гыйззәт

**Сөендерә башлау** Сөндерергә керешү

**Сөендерә килү** *к.* **сөендереп килү**. *Язучы укучыларын берсеннән-берсе кызыклы китаплар белән сөендерә килә*

**Сөендереп алу** Беркадәр вакыт, бераз сөендерү

**Сөендереп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә сөендерү. *Соңгы елларда районыбыз авылларындагы җирле хастаханәләрнең төрле сәбәпләр белән эшләүдән туктавын ишетеп йөрәк әрни иде, ә бу хәбәрләр күңелне күтәреп, сөендереп җибәрде.* Шәһри Казан

**Сөендереп килү** Күптәннән бирле сөендерү; эзлекле рәвештә сөендерү. *Рәссамнар --- яңадан-яңа эшләре белән тамашачыларны сөендереп киләләр.* Шәһри Казан. *Кызыбыз укуындагы яхшы нәтиҗәләре белән сөендереп килә*

**Сөендереп кую** Кинәт, уйламаганда бер мәртәбә сөендерү. *Җибәргән кайбер хаталар сөендереп тә куя мине. Чөнки алар тегe яки бу текстка гаделлек өстиләр, чынбарлыкны дөресрәк аңларга ярдәм итәләр.* Шәһри Казан

**Сөендереп тору** Әле, хәзерге вакытта сөендерү; гел, даими сөендерү. *Якташларыбыз Россия күләмендәге җиңүләре белән сөендереп тора.* Шәһри Казан. *Табигать игенчеләргә хәерхаһлы булды: җылы, коры, матур көннәре белән сөендереп торды.* Татарстан яшьләре. *Ризыкларны төрләндереп, якыннарымны сөендереп торам.* Туган як

**СӨЕНЕЧ** *и.* **1.** 1) Сөенү, куану, канәгатьлек хисе; шатлык. *Пәйгамбәрлекнәбилек син алачаксың Һәм мәмләкәт иясе син булачаксың, Рәхәтләр һәм сөенечләр табачаксың ---.* Кол Гали. *«Канлы байраклар» югары селкенә, Саф йөрәкләр сөенеченнән җилкенә. Оныта алмам мәңге бу шатлык көнен: – Яшәсен чын хөррият!.. – актык сүзем.* М.Гафури

2) Сөенечле, шатлыклы, күңелле хәбәр. *Мин Галимҗан ага Ибраһимов янына барам! Мин Ялтага китәм! Бу көтелмәгән тау хәтле сөенечне кемгә булса да әйтергә, шатлыкны бүлешергә кирәк.* И.Салахов. *– Булды, – диде Габдулла абый, – сезне аерым палатага салачаклар. – Әнинең күзләре шул сөенечтән яшьләнгән икән.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* Сөенечле, шатлыклы, күңелле. *Патша, шундый зур сөенеч хәбәрне ишеткәч, тәхетеннән торып, кызы янына юнәлде.* К.Насыйри

◊ **Сөенеч алу** *к.* **сөенче алу**. *[Әкълимә:] Гөләндәм апа, җаным! Баягысы барышлый булса, бусы кайтышлый. Сөенеч алырга кердем.* Ф.Хөсни. *– Зөлфия, әбигә бүләк бир. Сөенеч алган өчен, – дип сүзгә кысылды Сәет.* Т.Галиуллин. **Сөенеч бирү** Шатлыклы хәбәр җиткереп сөендергән кешене бүләкләү. *Әниеңә барып сөенеч бирим.* Г.Исхакый. **Сөенече эченә сыймау** Нәрсәгәдер нык сөенү, шатлану, куану. *Алар --- җиләклекнең уртасына килеп чыктылар. Икесенең дә сөенече эчләренә сыймады, дөньяларын онытып, җиләк җыйдылар.* З.Кадыйрова

**СӨЕНЕЧЛЕ** *с.* **1.** 1) Сөендерә торган, шатлыклы, күңелле; шатлык-сөенеч китерә торган. *Монда мин белгән Юллар сөенечле. Илемне сөйгән Өчен мин көчле...* З.Нури. *Сугыш... Кара болытлай ябырылып, өермәдәй өерелеп, иргетләрне авылдан, кыр-болыннардан, сөенечле көннән, якыннары кочагыннан йолкып-кубарып, чыклы иртәдә ут эченә алып китте...* Казан утлары

2) Сөенү-шатлану хисләрен белдерә торган, куанычны күрсәтә торган. *– Улым, тор әле, – диде Таибә абыстай әкрен генә, серле һәм сөенечле бер тавыш белән.* Ә.Еники. *Сәетнең бөтен барлыгын сөенечле, шатлыклы, шул ук вакытта төерле, кантарлы дулкынлану биләде.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Сөенеп, куанып. *Артымнан Салих та килеп җитте. – Бәгырь, ник болай куян шикелле качтыгыз? – диде ул, сөенечле көлемсерәп.* Ә.Еники. *Сөйләштек. Кыз сөенечле елмаеп баш какты. Мирхас атын кырт кына борып, ишегалдыннан чыгып китте.* Х.Камалов

**СӨЕНҮ** *ф.* Куану, шатлану. *Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.* Ә.Еники. *Җаның барда сөен, тыңла яшәү көен. Авыз йомып торма, кушыл да бер җырла.* Р.Харис

**Сөенә башлау** Сөенергә тотыну. *Дөресен әйткәндә, мин никтер бу чемоданның барлыкка килүенә сөенә башладым.* З.Хәким

**Сөенеп алу** Кыска вакыт сөенү. *«Ярый ла тәвәккәлләп кайттым әле!» – дип сөенеп алды Әһлия.* К.Тимбикова

**Сөенеп бару** Даими сөенү. *Якташыбызның эшчәнлеген күзәтеп, уңышларына сөенеп барабыз*

**Сөенеп җибәрү** *к.* **сөенә башлау**. *Патша сөенеп җибәрә ---.* Әкият

**Сөенеп йөрү** Даими, озак вакыт сөенү. *Малай-шалай сөенеп йөри ---.* Г.Афзал. *Мин әле кызларның кайсына өстенлек бирүемне анык кына аңлап бетермәсәм дә, атналар буена кош токандай сөенеп йөрим.* Ф.Хуҗин

**Сөенеп китү** Ниндидер сәбәптән кинәт сөенү. *Синдбад шул турыда исенә төшергәч сөенеп китә.* Әкият

**Сөенеп кую** Бер тапкыр сөенү; бераз сөенү. *Людмила Борисовна, ниндидер яшерен серләрне белгән кеше төсле әйтеп, шушы сүзләреннән сөенеп тә куйды.* Ф.Яхин. *Олы юлга төшкәч, Гайнан тагын бер сөенеп куйды: күңелендә таралып яткан хисләрен, уй-фикерләрен тупларга, тәртипкә китерергә җай чыгачак бит...* Г.Гыйльманов

**Сөенеп тору** Хәзер сөенү, сөенү хәле кичерү; даими, гел сөенү. *Иҗат җимешләреңне системалы укып, сөенеп торам. Үгездәй тап-таза әдипләребезне уздырып иҗат итәсең. Рәхмәт!* Ф.Яруллин. *Элек булса, бөтен авыл килеп булышыр иде, ә хәзер әнә, [йорты янганга] бөтенесе сөенеп кенә тора.* Ф.Бәйрәмова

**СӨЕНЧЕ** *и.* 1) *иск. к.* **сөенеч 1.** (*2 мәгъ.*). *Ул Җәбраил әйтте: «Тугры Арын әйт тә бирен әйт, Барын әйтмә, берен әйт: Унҗиде дус, сөенче, Тора килеп киенче».* Дастан. *Сөенче, сөенче, милләт тәрәккый итә!* Г.Исхакый

2) Куанычлы хәбәр ирештерүчегә бирелә торган күчтәнәч. *– Кияү өйдә, сөенче бирсәң, кияүне күрсәтербез, – диде Чуляк вәзир.* Әкият. *Исмәгыйльнең эштән кайтып керүенә, хатыны Гөлбанат: – Биетәм хәзер үзеңне, сөенче бир! – дип каршы алды.* Ф.Яхин

◊ **Сөенче алу** 1) Шатлыклы хәбәрне беренче әйтеп, берәүне сөендерү. *Әти кешенең авызы колагына җитте, рәхмәтләр әйтә-әйтә, сөенче алырга, бәби тәпие юарга чыгып йөгерде.* З.Кадыйрова; 2) Шатлыклы хәбәр ирештергән өчен нинди дә булса бүләк, тәм-том алу. *Шул шау-шу эчендә баягы шаһитларның яшьрәге Вәлиморат акрын гына торды, чикмәнен, бүреген, чабатасын киде дә өндәүче Чокыр Хәбип йортына, кияүдән никах сөенче алырга дип чыгып йөгерде.* Г.Ибраһимов. *Әтинең кайтканын беренче күрүче, гадәттәгечә, сөенче алган.* Татарстан яшьләре. **Сөенчегә сул (уң) колагың үзеңә** Шатлыклы хәбәр таралып өлгергәннән соң, ул хакта белмичә, сөенеч алам дип, берәр бүләк өмет иткән кешегә яки бирер бүләк булмаганда әйтелә торган сүз. *Үзе чаба, үзе оран сала: «Сөенче! – ди [малайчык]. – Миңа алдырык!» «Сөенчегә – сиңа сул колагың!» – Кемдер үрти йөрәк яндырып.* А.Юнысова. **Сөенче – өстең-башың киенче** Элек татар

халкында сөенечле хәбәр китергән кешене затлы кием-салым белән бүләкләү гадәтенә бәйле әйтелә торган сүз

**СӨЗӘГӘЮ** *ф. к.* **сөзәкләнү**. *Ат юлы Әхтәм урамы башыннан берничә дулкын ясап сөзәгәеп төшә дә, Кабан өстеннән кыйгач кына сузылып, --- тыкрыкка барып тоташа.* Т.Нурмөхәммәтов

**Сөзәгәеп калу** Ниндидер тәэсирдән соң сөзәгәю

**Сөзәгәеп килү** Аз-азлап, акрынлап сөзәгәю

**Сөзәгәя бару** Торган саен ныграк сөзәгәю. *Без килгән урамның асфальты бетүгә, тәпиләп сөзәк үрдән төшәсең дә әнә шул йоп-йомшак чирәмлеккә аяк басасың. Ә яр буе тагын да сөзәгәя бара ---.* М.Вәлиев

**Сөзәгәя башлау** Сөзәгәю билгеләре күренү

**Сөзәгәя төшү** Бераз сөзәгәю; тагы да сөзәгәю

**СӨЗӘК** *с.* Әкренләп түбәнәя барган, берникадәр авыш, текә түгел. *Хәвеф-хәтәр булмадымы дип, берсе артыннан берсен сорашканда, сөзәк кенә тауны төшәргә килеп җителгән иде.* А.Таһиров. *Шаша, таша елгалар – Тотып торалар ярлар: Берсе текә, берсе сөзәк... Берсе – акыл, берсе – йөрәк.* Н.Сафина. *Ләкин утырма токымнардан торган бу таулар да сөзәк, түбәләре яссы.* Материклар һәм океаннар географиясе

**СӨЗӘКЛӘНҮ** *ф.* Сөзәккә әйләнү. *Бакча бик озын, сөзәкләнеп, инеш ярына чаклы төшә.* Ә.Еники. *Блиндаж авызыннан түбәнгә сөзәкләнеп, матур үзән сузылып киткән иде.* К.Хисамов

**Сөзәкләнә бару** Торган саен ныграк сөзәкләнү. *Күз салам югарыга. Иң биек җире, аннан ары тау сөзәкләнә бара, үзәнгә әверелә ---.* М.Кыям

**Сөзәкләнә башлау** Сөзәкләнү билгеләре күренү. *Аяк астында җир сөзәкләнә башлады, сулышка да җиңелрәк булып китте.* Н.Хәсәнов

**Сөзәкләнә төшү** Бераз сөзәкләнү, тагы да сөзәкләнү. *Сул як текә, тик уң яктан сөзәкләнеп төшкән бер җирдән барып кына, чокырны читләтеп үтәргә мөмкин.* Х.Камалов

**Сөзәкләнеп калу** Ниндидер тәэсирдән, вакыйгадан соң сөзәкләнү. *Сөзәкләнеп калган ярдан җайлап түбән төшәм.* Г.Хөсәенов

**Сөзәкләнеп килү** Аз-азлап, акрынлап сөзәкләнү. *Елганың көтү йөри торган яр буе сөзәкләнеп килә*

**Сөзәкләнеп китү** Кискен, кинәт кенә сөзәкләнү. *Бу урында яр сөзәкләнеп китә, ә упкын арырак.* Ф.Яхин. *Су станциясеннән соң тау аз гына сөзәкләнеп киткән кебек була.* Т.Нурмөхәммәтов

**Сөзәкләнеп тору** Һәрвакыт, даими сөзәкләнгән хәлдә булу. *Инешнең бирге ягы ап-ак булып сөзәкләнеп тора, анда кая карама вак таш сибелгән иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**СӨЗӘКЛЕК** *и.* 1) Сөзәк булу сыйфаты. *Сөзәклек нинди рельеф формасының өлеше булып тора (калкулык, ерым, елга ярлары һ.б.), ул горизонтның кайсы ягына карый ---.* Башлангыч география курсы

2) Сөзәк җир, урын. *Буталыш китте, мотоцикллар бер-берсенә бәрелешеп бетте, берсенең тәгәрмәче ычкынып, сөзәклектән чокырга хәтле тәгәрәп килде.* Х.Камалов. *Текә тауны кайчандыр уеп кискәннәр, йөк белән йөргәндә, сөзәклек уңайлы.* М.Хуҗин

**СӨЗГӘК** *с.* **1.** 1) Сөзү гадәте булган, сөзешә торган. *Чем кара – елан түгел, мөгезле – сөзгәк түгел, канатлы – песнәк түгел, очканда мыш-мыш килә, туфракка яшеренә. Бу нәрсә, я, кем белә?* Табышмак. *Гадәттә, сөзгәк үгезләрнең мөгезенә агач калып кигезеп яхшы итәләр, чөнки калыбына карап, үгезнең сөзгәк икәнен ерактан күреп, саклану чаралары күрергә мөмкин.* Р.Батулла

2) *куч.* Туры, текәлеп караган. *Беттем: баттым зәңгәр тирәнлектә! Коткармагыз. Күзләре – мөгезләре, сөзгәк күзләр! Аһ, тагын бер сөзсәче!* Ш.Галиев. *Пешкән карлыгандай кара, сөзгәк күзле, өлгергән гәүдәле ханымның үзенә кадерле җан икәнен җаны, тәне, яралы күзәнәкләре белән тойды Сәет шул мизгелдә.* Т.Галиуллин

3) *куч.* Туры сөйли, сүзен йөзгә бәреп әйтә торган. *Сөзгәк, типкәк, тешләк кешегә дә без «сатирик» дибез түгелме соң?* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Сөзү гадәте булган, сөзешә торган мал. *Илсөяр, сөзгәкне каргый-каргый, эзләргә китте.* Р.Хәбибуллина

◊ **Сөзгәк сыерга Ходай мөгез бирми** Эш майтарган кыяфәт белән бар нәрсәгә тыкшынып йөргән булдыксыз кеше турында. *Ләкин Ходай сөзгәк сыерга мөгез бирми интектерә. Фазыл белән Гөлфәния арасындагы мөнәсәбәтне белүчеләр исә мыек астыннан елмайды: гыйшык уты диләр аны!* Н.Әхмәдиев. *Утырганда, буйга кыскалыгы бик сизелмәсә дә, кыска аякларына баскач, тагын да кечерәеп, утырган урындыгыннан аз гына югарырак булып калды. Сөзгәк сыерга Ходай Тәгалә мөгез бирми шул.* Т.Галиуллин. **Сөзгәк сыер мүкләк була** *к.* **Сөзгәк сыерга Ходай мөгез бирми**. **Сөзгәк сыер сыман** Бар нәрсәгә тыкшынып, бер сәбәпсез бәйләнеп йөргән кеше турында. **Сөзгәк тана** Теләсә кая тыкшынып, әрсезләнеп, комсызланып йөргән кеше. **Сөзгәк үгез** *к.* **сөзгәк тана**. *Власть башында утыручы сөзгәк үгезләр өчен без аңгыра сарыклар гына бит.* Ф.Яруллин

**СӨЗГӘКЛЕК** *и.* Сөзү гадәте. *Үгез бозауның мөгез чыгасы урынын кашып, сөзгәклеккә дә өйрәтә идек.* Ватаным Татарстан

**СӨЗГЕ** *и.* 1) Тоткычлы кыршауга беркетелгән вак күзәнәкле ятьмә капчыктан гыйбарәт балык сөзү, балык аулау коралы; сөрәкә; *русчасы:* **сачок**. *Балыкчылар, зур сөзгеләренең озын саплары югалып беткәнче суга чумдыра-чумдыра, балык аулыйлар.* Г.Ибраһимов

2) Ике колга арасына тотылган ятьмәдән гыйбарәт гади балык тоту коралы; *русчасы:* **бредень**. *Ерактан балыкчыларның җырлап сөзге тарткан тавышлары ишетелә.* М.Җәлил

**СӨЗГЕЧ** *и.* 1) Сыеклыкларны сөзеп, чит катнашмалардан, чүптән чистартуарындыру өчен кулланыла торган иләк сыман җайланма. *Ул, сөзгеч өстенә ике кат марля куеп, сөтне сөзде.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **сөзге**. *Сөзгечнең җебен тотып, алмаш-тилмәш утырып карадык.*

*Кичтән кәсебебез уңмады.* М.Кәрим. *Елга буена барганбыз да, аягым шуып, суга төшеп киткәнмен. Балыкчы Закирҗан абый янда булып, йомры сөзгече белән эләктереп алмаса, бу дөньяда каберем дә булмас иде инде.* М.Кәбиров

**СӨЗДЕРҮ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **сөзү**. *Күмер күзле, ялкын йөзле бу малай үзенең кәҗә тәкәләреннән өйдәге бөтен нәрсәне сөздереп бетергән: кече яктагы савыт-сабалар да, стенадагы әби йөзедәй саргайган көзге дә, сәкегә өелгән мендәр-ястыклар да калмаган.* Ф.Яруллин

2) Эттерү; бәрдерү; көч ярдәмендә башка урынга күчерү. --- *Бакый, машинасы белән сөздереп, капканы аударды, коймаларны иште.* Н.Гыйматдинова

3) Якын китерү, терәтү; төрттерү. *Идегәй алай дигәндә, Саллар салга килгәндә, Норадын салны сөздереп, Салны салга бәйләде.* Дастан

**Сөздерә бару** Рәттән, барысын да сөздерү

**Сөздерә башлау** Сөздерү гамәленә керешү

**Сөздереп алу** Тиз арада сөздерү

**Сөздереп бетерү** Барысын да сөздерү

**Сөздереп ташлау** Кинәт, көтмәгәндә сөздерү. *[Айрат] --- көннәрдән бер көнне бульдозер алып кайтты да өй артындагы бәрәңге бакчасының яртысын кызыл балчыкка кадәр сөздереп ташлады.* Ф.Яруллин

**СӨЗЕК** *и.* **1.** 1) Сөзгәннән соң сөзгечтә җыелып калган масса. *Бал сөзеге*

2) *диал.* Сөт өсте

**2.** *с. мәгъ.* Тонык түгел, үтәкүренмәле. *Сөзек су*

**СӨЗЕМТӘ** *и.* 1) *к.* **сөзек** (*1 мәгъ.*). *Компот сөземтәсе*

2) *күч.* Нәрсәне дә булса иң соңында гомумиләштереп ясалган фикер; йомгак, нәтиҗә; сыгымта. *Хәер, СССРда да, мәктәпләрдә «марксизм-ленинизм» һәм «сталинизм» өйрәтүләре сөземтәсеннән чыгып укытылган бу сәер илдә дә, төрки-татарлар үҗәтләнеп белем алырга омтылалар.* Г.Исхакый. *Егет аз сүзле, саран сүзле булса да, әйткәне, гадәттә, мәгънәле, төпле күзәтү сөземтәсе булып чыга.* Т.Галиуллин

**СӨЗЕМТӘЛӘ́Ү** *ф.* Кыскартып, төп өлешен билгеләү; аеру; сөземтә ясау. *Нуруллин килеп керде. Равилгә минем кайбер фикерләрне сөземтәләп әйтте.* Х.Туфан

**СӨЗМӘ** *и.* Катыкның суын саркыткannan соң калган куе масса, әчкелтем сөт азыгы. *Саҗидә аны [Фәһимне] ак келәтләренә алып керде. Тәмле сөзмә белән сыйлады, чормадан бер җиңсә урман чикләвеге алып төште.* Г.Бәширов. --- *Фагыйлә абыстай тиз арада хәбәр салды: – Абзагызга сөзмә китерегез!..* Ф.Яхин

**СӨЗҮ** I *ф.* 1) Мөгезе, маңгае белән төртү, чәнчү, бәрү; башы, күкрәге белән этү (гадәттә, хайван тур.). *Нәрсә? Синең сыер минем сыерны сөзеп үтергәнме? Нигә соң, ахмак, карамадың?* Т.Гыйззәт. *Нигъмәтулланы әйтәм, карт үгезен җәлләп елап утырган була, кадалып китсен карт үгезе, баламны сөзеп үтерә язды.* З.Кадыйрова

2) Баш белән су, һава һ.б.ш.ны ерып, эткән кебек хәрәкәт ясау. *Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм; Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.* Г.Тукай. *Агент, маңгае белән алга таба сөзеп, кызга төбәлде.* Х.Камалов

3) *күч.* Дикъкать белән, текәлеп карау; күз карашы белән иңләп, айкап чыгу. *Ул голт-голт эчте дә, арыган күзләре белән тирә-юньне сөзеп: – Ә Неплюйко? – дип сорады.* И.Гази. *[Вәкил] каш астыннан тагын бер сөзеп карады. – Әтиең белән бәйләнешең бармы?* М.Мәһдиев. *Зариф тирә-якны сөзеп күздән кичерде.* А.Хәлим

◊ **Сөзәм дигән сыерга Ходай мөгез бирмәгән** *к.* **сөзгәк сыерга Ходай мөгез бирми**. *Янына килергә куркырсың, дип әйтер идең – буе кечкенә. Сөзәм дигән сыерга Ходай мөгез бирмәгән, ди.* М.Мәһдиев. **Сөзәм дигән сыерның мөгезе сынган** «Миңа янап, үзең җиңелә күрмә» дигән мәгънә салынган кисәтү

**Сөзә башлау** Сөзергә керешү

**Сөзә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөзүен дәвам итү

**Сөзә язу** Чак кына сөзми калу

**Сөзеп алу** Тиз арада сөзү; бер мәртәбә сөзү. *Аны [Сәгыйдәне] Газизнең ярдәмчесе авыр гына караш белән сөзеп алды да: – Сез Газизгә килдегезме? – диде.* Һ.Такташ. *Ул, теләктәшләр эзләп, күзләре белән бүлмәне сөзеп алды.* М.Әмирханов

**Сөзеп ату** Тиз генә сөзү. *Бездә – бозау. Сөзеп ата, аз гына кыймылдасаң. Сарбай исә бик тешләми, Үзенә кагылмасаң...* Г.Гыйльманов

**Сөзеп бетерү** Барысын да сөзү

**Сөзеп җибәрү** Кинәт сөзү. *Кәҗә тәкәсе аны сөзеп җибәрде*

**Сөзеп кую** Кинәт бер мәртәбә сөзү

**Сөзеп ташлау** Тиз арада сөзү

**Сөзеп тору** Әле, хәзерге вакытта сөзү; әледән-әле, даими сөзү

**Сөзеп үтү** *к.* **сөзеп чыгу**. *Мәнсез бу адәм безне, куркуга баткан бәндәләрне, карашы белән сөзеп үтте һәм Алиядә тукталды ---.* Ф.Гыймалтдинов

**Сөзеп чыгу** Берсен дә калдырмыйча, барысын да рәттән сөзү. *Алар, ишек катында туктап, фойедагы яшьләрне күзләре белән сөзеп чыктылар.* Г.Галиев. *[Әхмәт Фәйзи] --- ишек төбендә туктап калды да, кара кысалы күзлек пыялалары аша бүлмәне сөзеп чыккач, Афзал Шамов янына барып утырды.* Л.Ихсанова

**СӨЗҮ** II *ф.* **1.** 1) Чүптән, чит катнашмалардан чистарту-арындыру өчен, берәр сыеклыкны сөзгеч, иләк, марля һ.б.ш. кебек вак тишекле әйбер аркылы агызып үткәрү; чүбен, чит катнашмасын аерып калдыру. *Яңа кар нинди ак, сокланырлык пакь! Чәйгә дип кайнатып, марля аркылы сөзгән идек, сөрем утырып калды.* Ш.Галиев. *Дөрес, бер атнадан ут күршеләребез шәһри Казанны электр уты белән, ә су күршеләребез биофильтр аша сөзгән чиста су белән тәэмин итештеләр.* А.Тимергалин

2) Гадәттә, балык һәм башка су җәнлекләрен ятьмә, сөзгеч һ.б.ш. җайланмалар ярдәмендә аулау, тоту. *Мин тормышның ашау-эчү, кар көрәү, маймыч сөзү, таң ату һәм кич булу кебек хәлләрдән генә тормавын --- тойдым.* Р.Вәлиев. *Авыл очында буа бар. Сазан, карп. Ятьмә бирәм, сөзегез!* З.Зәйнуллин

3) Аралап, актарып җыю. *Уң кулын чалбар кесәсенә тыгып, аның төбеннән вак акчалар сөзеп чыгарды.* М.Кәбиров

4) *күч.* Барлап, аерып, сайлап, әйбәтрәген алу, кулга төшерү. *Элек чыккан китапларда --- шагыйрьнең шигырьләре кульъязмалардан, чыккан китаплардан сайлап төзелгән, сөзеп алынган дигән сүз.* Н.Нәҗми

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыкмыйча, аз-азлап, йотым-йотым гына. *Фазылның сынап караганы бар, ләкин ул Мөнирҗан шикелле алай уптым илаһи эчә алмый. Яңа туган бозау сыман сөзеп-сөзеп эчә. Анда да авырлык белән.* Н.Әхмәдиев. *Йолдызларын читкә этәреп, сөзеп кенә зәңгәр һава эчәм. Җидегән йолдыз чүмече елгага тиеп тора.* Ш.Галиев

2) Кирәген генә сайлап, кыскартып, гомумиләштереп, сөземтәсен генә аерып. *Минә ул мөмкин кадәр кыска итеп, сөзеп-сыгып кына сөйләде дә бирде.* Н.Фәттах. *Кемнәргәдер өеп бирә. Укаларга төреп кенә. Кемнәргәдер сөзеп бирә – Энә очына элеп кенә.* Казан утлары

**Сөзә башлау** Сөзәргә керешү

**Сөзә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөзүен дәвам итү

**Сөзеп алу** Бераз сөзү, тиз генә сөзү

**Сөзеп ату** Тиз арада сөзү гамәлен башкару

**Сөзеп бетерү** Барысын да тоташтан сөзү. *[Райпищекомбинат директоры] «Елгадагы балыкны сөзеп бетермәдеме икән?» – дип шикләнеп куйдым мин.* Ә.Еники

**Сөзеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта сөзү гамәлен башкару; даими сөзү белән шөгыльләнү

**Сөзеп карау** Сөзәргә омтылу, сөзәргә тырышу; сынау максаты белән сөзү. *[Сәетҗан:] Коръән алып ант итәм, сүзләрем дөрес. Минә сезгә ак яулык – суны сөзеп карагыз, үз күзегез белән күрерсез.* Т.Гыйззәт

**Сөзеп кую** Алдан хәстәрен күреп сөзү; тиз арада сөзгән хәлгә китерү

**Сөзеп ташлау** Тиз арада, озакка сузмыйча, сөзгән хәлгә китерү

**Сөзеп тору** Әле, хәзерге вакытта сөзү; даими рәвештә сөзү гамәлен башкару

**Сөзеп чыгу** Барысын да бер-бер артлы сөзү. *Бер яктан сөзеп чыккач карасалар, сөрәкәнең койрыгы тулы тәрле зурлыкта фәкать җәен балыклары гына килеп чыкты.* Т.Нәбиуллин

**СӨЙГӘН** *с.* **1.** Яраткан; сөекле; якын иткән, үз иткән. *Маһитапның сүзләрендә, мөнәсәбәтендә ул һәрвакыт кыз туганының кайгыртучанлыгын һәм сөйгән кызының назын тоя.* А.Таһиров. *Аның сөйгән кызы бар. Бәлки, вәгъдәләшкән үк булгандыр.* М.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ.* Яраткан, ошаткан кеше, сөйгән яр; якын, сөекле кеше. *Сөйгәнем, хат язам Сугышның үзеннән... Тик шәүләм сүнмәсен, Китмәсен күзеңнән.* Р.Вәлиев. *Егет эндәшми, сөйгәненең татлы иреннәренә иелә...* Казан утлары

**СӨЙДЕРГЕЧ** *и.* **1.** Берәүне сөйдерү нияте белән кулланыла торган им-том чарасы. *Шул ук фатирда һәртөрле сөйдергеч имнәре, боздыргыч тылсымнары, туздыргыч дәвалары --- табарга мөмкиндер.* Г.Тукай. *Ярдәм итми, сөйдергеч тә таккан идем.* Р.Батулла. *Яшь кызлар, берәр егеткә гашыйк булып, аны үзенә каратыр өчен, имче карчыклардан сөйдергеч бөтиләре яздыра торган булганнар.* Ватаным Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* Сөйдерә, яраттыра торган. *--- хәзрәтләрнең череп беткән бәддогасына алданып куркып тормак заманы кәчмештер һәм дә ялганчы әбиләрнең сөйдергеч, биздергеч догаларына ышану заманасы калмыштыр.* Г.Тукай. *Ә син, фәрештәләр фәрештәсе, нигә таң алсулыгы кунган битләрең уртасындагы фәрештә үпкән сөйдергеч урыннарны чокыр дип йөртәсең?* Т.Миңнуллин

**СӨЙДЕРҮ** I *ф.* 1) *йөкл. к.* **сөю**. *Бер генә сөйдер!* А.Хәлим. *Бу хатын аны сөя дә, сөйдерә дә белә.* М.Хәбибуллин. *Ләкин, ничек кенә үптерсә дә, назлатып сөйдерсә дә, актин-ак, сафтин-саф тәненә Ленарның дәртле, мәхәббәтле һәм ымсындыргыч тәнен якын җибәрми иде...* [Зәлидә]. Г.Гыйльманов

2) Үзеңә караттыру; яраттыру; сөяргә этәрү. *Аларны суындырырга дигәнен түшәкләренә тегәргә кирәк, үзеңне сөйдерергә дигәнен иреңә изеп эчерергә кирәк.* Г.Исхакый. *Кортка әле тагын сөйдерә дә, боздыра да, ди, имеш. Сөйдерүе бер хәл, боздырса бит эшләр яман.* Р.Зәйдулла

**СӨЙДЕРҮ** II *и.* Үзен сөяргә юл кую, каршы килмәү. *Бән сиңа сөйдерү бөтиләре өшкереп бирермен ---.* М.Әмирханов

**СӨЙКӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сөйкәү**

2) Берәр җиргә аз гына орынып тору, таяну яки бераз гына вакытка сөялү. *Минә әле дә, тупса аша үтеп, үзенең тамагын туйдыручысының фаҗигале халәттә булуын аңлап алгандай, җәһәт кенә сәкегә сикереп минде һәм тартыша-тартыша елаган хуҗабикәсенең кулбашына сырты белән сөйкәлеп ятты.* А.Хәлим. *Өстәлгә сөйкәлеп, куллары белән битен каплый.* К.Җәмитов

3) *күч.* Берәүгә сыену, таяну; назлану. *Сөйкемсезгә сөйкәлмә.* Мәкаль. *Сөймәгәнгә сөйкәлмибез, сөюче булыр әле.* Р.Сәгъди. *Сөймәгәнгә сөйкәлмиләр, үз кадерен беләләр.* Кызыл таң

**Сөйкәлә бирү** Беркемгә яки бернәрсәгә карамастан сөйкәлү

**Сөйкәлеп йөрү** Әле монда, әле тегендә барып сөйкәлү. *[Кыз – ярат-маган егетенә:] Моннан соң янымда сөйкәлеп йөрмәвеңне телим.* Ш.Камал

**Сөйкәлеп тору** Сөйкәлгән хәлдә булу

**СӨЙКӘНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **сөйкәү**

2) *к.* **сөйкәлү** (*3 мәгъ.*). *Сөймәгә бирсәң сылу бир – Ак сарайга сөйкәнеп Елый калса, кем алмас?* Дастан. *Сез дә ата баласы, Без дә ата баласы; Сөймәгәнгә сөйкәнмибез, Сөйсәң – яр табыласы.* Җыр

**Сөйкәнә бирү** *к.* **сөйкәлә бирү**

**СӨЙКӘҮ** *ф.* Җиңелчә, аз гына терәтеп сөяү. *Урәчәле чана түренә капчыкны сөйкәдем дә күп итеп салынган печән өстенә менеп кырын сузылдым.* Ш.Маннур

**Сөйкәп кую** Сөйкәлгән хәлгә китерү. *Бернәрсә дә чыкмагач, аунап яткан берничә күсәк-таяк сөйкәп куеп, үрмәләп менеп китә.* К.Җәмит

**Сөйкәп тору** Бертуктаусыз, рәттән сөйкәү

**Сөйкәп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы сөйкәү

**СӨЙКЕМ** *и.* Сөйкемлелек сыйфаты. *Түгәрәк йөзенең бит урталары*

*уйсуланып тора, елмайганда, ул уйсулык, тирәнәеп, нәни генә чокырчыкка әверелә һәм кызга аерым бер сөйкем өсти.* Н.Әхмәдиев. *Көлгән чакта бит алмаларында сөйкем чокырлары ярала торган, ифрат та матур тавышлы, теремек Шаран кызы [Өммегөлсем] Гарифулла укуын тәмамлыйсы елда кыска вакытлы курсларга килгән иде.* А.Хәлим

**СӨЙКЕМЛЕ** *с.* Матур, ягымлы, мөлаем; яраттыра, караттыра, үзенә җәлеп итә торган. *Шушы минутка хәтле аңа сылу, күркәм, сөйкемле булып күренгән Камилә, кинәт шөкәтсез, иләмсез, тупас булып күренә башлады.* А.Таһиров. *Ләйсән яңгыр барыбер яңгыр инде, Тик нигәдер күзгә сөйкемле. Яз сөенече белән керфекләрдә Энҗеләнгән яшьләр шикелле.* М.Җәлил. *Бик беләсең килсә, синнән сөйкемле, синнән чибәррәк егет юк та әле безнең класста!* В.Нуруллин

◊ **Сөйкемле сөяге булу** Башкаларның игътибарын җәлеп итәрлек, яраттырырлык, сөйкемле күрсәткән берәр сыйфатка ия булу. *Булса да булыр икән адәм баласында сынмас сөйкемле сөяк.* Ф.Яхин. *Аз сүзле, үз эченә бикләнгән бу адәмнең нindидер бер сөйкемле сөяге бар иде бугай.* Р.Мирхәйдәров. **Сөйкемле сөяк** Яраткан яки күңелгә хуш килгән, сөйкемле кеше; сөйгән яр, җанаш. *Беркатлы Бибисара яңадан үзенекен каерды: – Анысы инде, Хатирә, безнең Гөлшаһидәбез кебек үк сөйкемле сөяк булмас, – диде. – Бриллиант йөзек кашы! Болгар нәселеннән!* Г.Әпсәләмов. *Таныш булыйк: мин – Ләбибә, менә бу ак йөзлесе – Рәҗибә, ә теге сөйкемле сөяк Хаҗия булыр.* Ф.Яруллин. *Берәүләрдә беләк көче, икенчеләрдә акыл үткенлеге, я булмаса җор тел, кешеләрнең күңелен җәлеп итә торган сөйкемле сөяк, ниһаять. Кызганыч ки, язмыш Фирдүскә боларның берсен дә бирмәгән иде.* М.Маликова

**СӨЙКЕМЛЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кемне дә булса сөйкемле итү; сөйкем өстәү. *Ак шәле астыннан бераз чыгып торган чәчләренә, кара керфекләренә кунган ак бәсләр кызның ачык, чиста йөзен тагын да сөйкемлеләндереп, нурландырып җибәргәннәр.* Ә.Сафиуллин

**СӨЙКЕМЛЕЛӘНҮ** *ф.* Сөйкемлегә әйләнү, сөйкемлелек сыйфатына ия булу. *Соңгы вакытта ул [Гәүһәр] бераз суырыла төшкән, ябыккан, әмма карар күзгә бик сөйкемлеләнгән.* Г.Әпсәләмов. *– Нигә алай дип әйтәсең? – диде ул [Мостафин], тагы да сөйкемлеләнеп.* Х.Камалов

**Сөйкемлеләнә бару** Торган саен сөйкемлеләнү. *Баладан соң Рәйсә күзгә күренеп сөйкемлеләнә барды.* Р.Батулла

**Сөйкемлеләнә төшү** Беркадәр сөйкемлеләнү; тагын да сөйкемлеләнү

**Сөйкемлеләнеп бару** Акрынлап, вакыт узган саен сөйкемлерәк булу

**Сөйкемлеләнеп калу** Соңгы арада яки нindидер бер вакыйгадан соң сөйкемлерәккә әйләнү

**Сөйкемлеләнеп килү** Соңгы арада сөйкемлеләнү

**Сөйкемлеләнеп китү** Нindидер сәбәптән, вакыйгадан соң яки күпмедер вакыт узу белән сөйкемлеләнү. *Әйе, Вася соңгы вакытларда матураеп, сөйкемлеләнеп китте шул.* Ф.Яруллин

**СӨЙКЕМЛЕЛЕК** *и.* Сөйкемле, ягымлы булу сыйфаты. *Сөйкемлелектә икән хикмәт. Бар искиткеч чибәр кешеләр, ләкин ярты сәгать сөйләшеп торгач, аның тышкы матурлыгы югала бара, --- кешенең эчке дөньясы гүзәллек белән тулмаса, аның тышкы матурлыгы юкка чыга.* Р.Батулла. *Шуңамы, кызлардагы тышкы матурлыкка караганда, аларның сөйкемлелеген артыграк бәяләде Газиз. Чөнки сөйкемлелектә үзенә бер аерым күркәм сыйфат, тирән мәгънә барлыгын белде.* З.Мәхмүди

**СӨЙКЕМСЕЗ** *с.* **1.** Сөйкемлелеге булмаган, сөйкемле түгел, күңелгә ятышсыз. *Сөйкемсезгә сөйкәлмә.* Мәкаль. *Әмирхан Еникидә нindи генә татарлар юк. Сөйкемлеләре, сөйкемсезләре, киң күңелләре, икейөзлеләре, акыллылары, ахмаклары, зыялылары, наданнары – барысы да бар.* Т.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* Сөйкеме булмаган, күңелгә ятышсыз кеше. *[Сәрби:] Аларның койрыгы булган менә бу сөйкемсезне дә алырга иде.* Т.Гыйззәт. *Алексей күзләрен шаянландырып елмайды: – Нигә, без сөйкемсезләрмени? – Белмим. – Кыз сүзне озайтырга теләмәде.* Х.Камалов

◊ **Сөйкемсезгә сөйкәлү** Сөймәгән, якын итмәгән кешегә сыенырга омтылу. **Сөйкемсез сөяге булу** *к.* **сөйкемсез сөяк булу**. **Сөйкемсез сөяк** Күңелгә ятышсыз, кемдер үз итмәгән, яратмаган кеше. *Яратмады ул мине, сөйкемсез сөяк булдым мин ул аксак хәшәрәткә...* Казан утлары. *Сөйкемсез сөякләр белән яшәве дә бик авыр бит, атасы.* М.Хәбибуллин // Күңелгә ятышсыз сыйфат. **Сөйкемсез сөяк булу** Сөйкемсез итеп күрсәткән, күңелне биздергән берәр сыйфаты булу аркасында, кемгәдер ошамау, кем өчендер яратмаган кеше саналу. *Камил әфәнде үзенең сөйкемсез сөяге барлыгын белә иде.* Ф.Яхин

**СӨЙКЕМСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Сөйкемлелек сыйфатын җую, сөйкемсезгә әйләнү. --- *аның каршында пырдымсызланып, нәфрәтеннән тагын да сөйкемсезләнгән, кадер күрмәгәнлектән тупасланып иртә картайган, керле чәч очлары берет астыннан тырпаеп чыккан Ниса нindи ямьсез, котсыз күренде.* М.Маликова

2) Сөйкемсезлек күрсәтү, сөйкемсез итеп күрсәтә торган берәр гамәл кылу; сөйкемсез булып кылану. *Нигә кинәт кенә шундый сөйкемсезләнде соң Изаелым?* Р.Гаязетдин

**Сөйкемсезләнә бару** Торган саен сөйкемсезләнү. *Үткәннәре шушы көннән-көн сөйкемсезләнә барган карчыкның күзләренә язылып, уелыпчокылып калган түгелме?!* Т.Гарипова

**Сөйкемсезләнә төшү** Беркадәр сөйкемсезләнү, тагын да сөйкемсезләнү

**Сөйкемсезләнеп калу** Соңгы арада яки нindидер бер вакыйгадан соң сөйкемсезрәккә әйләнү

**Сөйкемсезләнеп килү** Сөйкемсезлек сыйфаты ачыграк, ныграк сизелү

**Сөйкемсезләнеп китү** Нindидер сәбәптән, вакыйгадан соң сөйкемсезләнү

**СӨЙКЕМСЕЗЛЕК** *и.* Сөйкемсез булу, шундый сыйфатка ия булу. *Аларга [татар мәдәнияте һәм мәгърифәтенә] милли сөйкемсезлек, милли күралмау, расизм, колониализм тенденцияләре ят нәрсә.* И.Әмирхан

**СӨЙЛӘК** *и.* 1) *фольк.* Берәр вакыйга яки шәхескә бәйләп, телдән сөйләнә торган кыска хикәя. *Безнең авылда кызыклы яки гыйбрәтле хәлләр турындагы сөйләкләрне, хикәятләрне, мәзәкләрне «дәмәк» диләр.* Г.Рәхим. *Икенче очрашуда, мәҗлестә баягынак [Зәйнәп апа] үзе уйлап чыгарган сөйләкне, Гөлсемнән, Халисәдән, Мәзкура, Зәмзәмия апалардан ишеттем дип, «кош балаларын» икенче түгәрәккә очырып җибәрер.* Т.Галиуллин. *Теркәлгән сөйләк персонажларын, аларның көнкүрештәге вазифаларын ачыкламый торып, үрнәкләрне турыдан-туры теркәү эшенә керешергә ярамый.* Ф.Җәүһәрова, А.Батталова

2) *әд.* Беренче заттан сөйләү формасында язылган, гадәттә, юмор белән сугарылган әдәби әсәр, хикәя; үзсөйләм, монолог. *Тукайның «Казанга кайтыш» дигән юлъязмасында сөйләк жанрына карый торган хикәя белән дә очрашабыз.* Л.Җамалетдинов. *Күчмә сюжет дигәннән, гасырдан гасырга, илдән илгә, халыктан халыкка күчеп йөри торган гыйбрәтле, еш кына фантастик вакыйга турындагы сөйләкне атыйлар.* Казан утлары

◊ **Сөйләк әйтү** Дөреслеккә туры килеп бетмәгән сүз сөйләү; күпертеп, үзеннән өстәп сөйләү. *Эчмим дип сөйләк әйтә алмый ул.* **Сөйләккә керү** Киң таралыш алу, риваять булып китү

**СӨЙЛӘКЧЕ** *и.* 1) Сөйләк сөйләүче

2) Сөйләкләрне фәнни нигездә өйрәнүче, тикшерүче

**СӨЙЛӘМ** *и.* 1) Аралашу-аңлашу чарасы буларак тел. *Туган тел кагыйдәләренең, сөйләм нормаларының бозылуы аерым сүзләрнең грамматик (морфологик) формаларында да ачык чагылыш таба.* Р.Юсупов. *Әдәби телебезнең нигезе итеп Казан арты, ягъни Арча ягы төбәге сөйләме алынган, дип рәсми рәвештә раслануга карамастан, җөмһүриятебезнең Сарман-Мөслим төбәгендәге сөйләм аңа бирешкесез.* К.Миңлебаев

2) Кеше үз фикерен, уйларын язмача яки телдән белдерү өчен кулланган сүзләр, тәгъбирләр, җөмләләр җыелмасы. *Һәр персонажның үзенә характерлы сөйләм табу – бик кыен эш.* Ф.Яруллин

3) Телдән файдалану алымы, формасы; тел стиле. *Текст эчендә мондый синтаксик чаралардан туры сөйләм дә санала ала.* И.Низамов. *Мелодраматик сөйләм калыплашуларның да үз аерымлыклары була.* Г.Нуриев

4) Сөйләү, хикәяләү, бәян. *Татар халык әкиятләрендә дә шулай бит: баштагы җөмләләр үткән заман формасында төзелә дә, аннары сөйләм хәзерге заман формасында бара.* Р.Юсупов

5) Тел авазларын әйтү, яңгырату, сөйләү. *Баланың сөйләме аңлашылмый*

**СӨЙЛӘМӘ** *с. кит.* Телдән әйтеләсөйләнә торган; *киресе:* **язма**. *Татар сөйләмә теле үсешендә дүртенче этап XX йөз уртасында башлана.* М.Зәкиев. *Шигырьнең мәрсия өлешендә гарәп-фарсы алынмаларының кабатлануы тагын да ешая, әмма алар сөйләмә форма белән уратыла ---.* И.Бәширова

**СӨЙЛӘМЧӘК** *с.* Күп сөйләргә, гәпләшергә яратучы, артык сөйләшүчән, сүзчән. *Француз сөйләмчәк һәм шат күңелле кеше иде. Аның аркылы Назимовлар Гансның да тарихын белделәр.* Г.Әпсәләмов

**СӨЙЛӘМЧӘКЛӘНҮ** *ф.* Сөйләмчәккә әйләнү

**Сөйләмчәкләнеп бетү** Тәмам сөйләмчәкләнү

**Сөйләмчәкләнеп китү** Ниндидер сәбәптән, вакыйгадан соң сөйләмчәкләнү

**СӨЙЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сөйләү** (*1–3 мәгъ.*). *Бу борылыш турында бездә күп һәм күптән сөйләнә.* Г.Кутуй. *Шекспирның бу трагедиясендә --- үсмерләрнең саф мәхәббәтләре зур фаҗига белән тәмамлануы турында сөйләнә.* Р.Сәйфуллина. *Ахмаклар гына бер сүз өчен чәчрәп чыгалар. Сүз сөйләнә дә бетә ул.* Казан утлары

2) Башкаларны тыңлап та тормыйча, аларга игътибар итмичә, туктаусыз сөйләү. *Кияү болардан күзен алмыйча карый, камил акыллы адәм кебек кире утыра, кызып сөйләнергә тотына ---.* Г.Ибраһимов. *--- Әлбинә һаман да бәхетледер дип уйлый иде, югыйсә кунак килеп керүгә, аның хәлен сорашмыйча, үзе турында гына ул кадәр җәелеп сөйләнер идемени ул?* Казан утлары

3) Беркемгә дә мөрәҗәгать итмәстән, беркемне дә күрмәстән, үзалдына сөйләү. *Гайнетдин абзый караңгылыяктылы бүлмәдә пошнап-пошнап чишенә вә үзе сөйләнә ---.* Ш.Камал. *Гафият ярты юлны бер сүз дәшмичә, әллә нидә бер башын чайкаштыргалап, үзалдына сөйләнгәләп барды да кинәт әйтеп куйды.* И.Гази. *Шулчак бер кулы яраланып кайткан кеше бүлмәгә туп итеп килеп керде. Ул ярыйсы ук салмыш иде. Кызып, кычкырып сөйләнә.* Казан утлары

4) Башка, аңлашылмаган телдә сөйләшү; аңлап булмаслык буталчык итеп сөйләү. *--- яралы немец нәрсәдер сөйләнә, Хәбиров өстенә төртеп күрсәтә.* Х.Камалов

5) Эшкә ашмастай, буш, нәтиҗәсез сүз сөйләү. *Өйләнү – түгел сөйләнү.* Г.Тукай. *Ә исерек кеше белән сөйләнә торган сүз – җил тек җил. Тот аннары җил койрыгын.* Казан утлары

6) Кирәгеннән артыгын сөйләп, серне ачу. *Микоянда булганыгызны сөйләнеп йөрмәгез. Һәм дәшмәскә өйрәнегез. Кызларыгыз фатирыгызда.* З.Зәйнуллин

**Сөйләнә башлау** Сөйләнергә тотыну. *– Сез кайттыгызмыни, ә? Зәйни, Бәхрия, сез дә мондамыни?! – дип сөйләнә башлады [Миңлебай].* Г.Ибраһимов. *--- былтыр да бер җыенда Хафиз бай: «Аны [Иркәбай] җирдән чыгарырга кирәк, ул барыбер әтрәгәләм булып киткән ---», – дип сөйләнә башлаган иде ---.* А.Таһиров

**Сөйләнә бирү** Һаман, бернәрсәгә карамастан сөйләнүне дәвам итү. *--- Сөләйманов --- беркатлылык белән ихлас күңелдән һаман сөйләнә бирә: – Әйе, Нургали абый, бер Кәримә сыерыннан гына түгел, барлык сыерлардан да шундый бозаулар аласы иде.* Ә.Еники

**Сөйләнә тору** *к.* **сөйләнә бирү**. *Зөлфирә бакчага керә килешкә үк сөйләнә торды: – Ай-һай, бүген көн кызу, көчкә килеп җиттем.* Казан утлары

**Сөйләнеп алу** Бераз гына сөйләнү. *– Хәдисендә пәйгамбәребез әйткән, ашның күчтәнәче, дигән, ашның үзеннән*

*өстен булыр, дигән, әйе, балакайлар! – диярәк сөйләнеп алды [Хафизаттәй].* Ф.Яхин. *– Миннән кемгә кала инде бу? – дип, үз-үзенә сөйләнеп алгалый торган булды [әби].* Р.Батулла

**Сөйләнеп йөрү** Даими, һәрвакыт сөйләнү. *Былтыр клуб җиткердек. Быел менә идарә йорты салып ятабыз. Шулай, энем, моннан ары алай сөйләнеп йөрисе булма!* Т.Гыйззәт. *Варис баш ия торган түгел, ярый хатын китте әле, дип көлгән, шатланган булып сөйләнеп йөри.* Х.Камалов

**Сөйләнеп китү** Кызып, мавыгып сөйләнергә керешү. *– Соң, абзаң хатын-кыз затының күзе төшмәслекмени инде? Табадан чыжылдап төшкән ничәмә кайнар кабартма әрәм калды, – дип сөйләнеп китте [полковник].* Т.Галиуллин

**Сөйләнеп кую** Кинәт аз гына сөйләнү. *[Партизаннарның] Берсе сөйләнеп куйды: – Бик аз гына үсәсең калган икән, тәти кыз.* Г.Гобәй

**Сөйләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта сөйләнү. *– Нәрсә сөйләнеп торасың? Әйдә, ач базыңны! – дип, берәү кычкырды.* Г.Ибраһимов

**Сөйләнеп утыру** *к.* **сөйләнеп тору**. *Сабир: Тиле син. Кергәннәр [колхозга], ник кердем, дип йөриләр. Ә син, авызыңны күтәреп, керергә кирәк, керергә кирәк, дип сөйләнеп утырасың.* Һ.Такташ. *– Мөмкин булса, тулырак итеп сөйләгез әле. – Юлда сөйләрмен, – диде Җиһангир абзый. – Юкса без сөйләнеп утырган арада, минем акыллы Сорнаем аяк сузып куймагае.* Ф.Яруллин

**СӨЙЛӘНЧЕК** *с. сөйл.* **1.** Буш, эшкә ашмастай сүзләр сөйләп, сөйләнеп кенә, әйткәнен үтәми торган (кеше тур.)

**2.** *и. мәгъ.* Күбрәк сөйләнеп, зарланып кына йөри торган кеше

**СӨЙЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сөйләү**. *Без, инде рус әдәбияты дәресе барыбер булмый дип, бүрекләр кигән килеш, Гыйззәтуллиннан бер атна эчендә ниләр күргәнен сөйләтә идек.* М.Мәһдиев. *Барый абыйдан сөйләттеләр, тагын кемдер кызыбызны бозыклыкта гаепләде.* Т.Миңнуллин

2) Сөйләү мөмкинлеге бирү, шул рәвешле кемгәдер игътибар күрсәтү. *Материалны әйбәт белә идем. Сөйләтмәде юньләп. Мескеннәр. Ике егетебез харап булды.* М.Мәһдиев. *Җиңгинең әйтүенә караганда, бүген картларның эшләре турында сөйлиләр, аларның үзләрен сөйләтәләр, бүләкләр бирәләр --- икән.* Л.Ихсанова

3) Радио һ.б.ш. аппаратларны кушу, тоташтыру, эшләтү. *Радионы көне буе сөйләтү*

**Сөйләтә башлау** Сөйләтергә тотыну. *Икенче көнне бу вакыйганы бөтен авыл тәмләп, тәфсилләп, әле Рәүфтән, әле Галимханнан сөйләтә башлады.* Р.Батулла. *Сәмитова апа мине сөйләтә башлады. Ләкин, бер җөмлә әйтү белән үк, хатамны тапты, менә болай ул, дип, үзе сөйләп китте.* Х.Камалов

**Сөйләтә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйләтүне дәвам итү

**Сөйләтә килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә сөйләтү

**Сөйләтә тору** Әле хәзерге вакытта сөйләтү; берәр хәл булганчы сөйләтү

**Сөйләтә төшү** Тагы бераз сөйләтү

**Сөйләтеп алу** Тиз арада сөйләтү

**Сөйләтеп бару** Даими, рәттән барысын да сөйләтү

**Сөйләтеп бетерү** Ахырына кадәр, тулысынча сөйләтү; кирәген дә, кирәкмәсен дә сөйләтү. *Кит, бу Нурия әллә ниләр сөйләтеп бетерде.* Г.Якупова

**Сөйләтеп җибәрү** Кинәт яки җәһәт кенә сөйләтү. *Кыйммәтле радиоалгыч күргәч, кунакларның да, хуҗаның да күзләре шар була. «Хәзер үк сөйләтеп җибәр инде!» – диләр бүтән кунаклар.* Ш.Галиев

**Сөйләтеп карау** Сынау максаты белән сөйләтү. *Мәктәп китапханәсеннән китаплар сорый башлагач, китапханәче Мәрзия апа китап эчтәлекләрен сөйләтеп карый иде.* Ф.Җиһаншина

**Сөйләтеп тору** Даими сөйләтү

**Сөйләтеп утыру** Беркадәр вакыт сөйләтү белән шөгыльләнү. *– Ишеттеңме? – диде ул, Мәмдүдә апа чыгып киткәч. – Юри сөйләтеп утырдым. Үзең турында ни әйткәннәрен белеп тор, авыз ачып йөрмәссең.* Р.Габделхакова. *Без аларның [артистларның] тормышын үзләренә караганда да күбрәк беләбез инде хәзер, аларны сөйләтеп утырганчы, котлауларны күбрәк укып, җырлар куйсыннар иде.* Э.Фатыйхова

**Сөйләтеп чыгу** Барысын да, рәттән ахырынача сөйләтү

**СӨЙЛӘ́Ү** *ф.* 1) Аралашу-аңлашу максаты белән телдән файдалану; фикерне тел чаралары ярдәмендә әйтеп бирү; сөйләү сәләтенә ия булу. *Бу җәмәгать яхшы сөйли белгән, шәп ораторларны табар иде.* Г.Афзал. *Үсте инде энем Айдар, бик зур булды, сөйли белә, әйтә белә бөтен сүзне.* Рәш.Әхмәтҗанов

2) Нәрсәдер хәбәр итү, әйтеп бирү. *Тәне бераз җылынгач, Зәйни тагы, сеңлесенең куркуына карамастан, үзенең убырлы карчыкны ничек сагалап йөрүен, хәерче малайларның кереп югалуын сөйләргә керешә.* Г.Ибраһимов. *Беркөн абзыеңның, көлтәдән кайтканда, шулай сөйләп, күзләреннән яшьләр килде.* А.Таһиров

3) Чыгыш ясау, доклад уку. *Матур сүзләр эзләвен оныткан Солтан: «Яхшы хәтерлә, – диде Розага, – докладыңны тартынып сөйләмә. Таныш мәсьәләң буенча җавапларны кыю бир».* Г.Кутуй

4) Нинди дә булса башка телдә сөйләшә алу; башка бер телне белү. *Русча шәп итеп сөйли белә.* З.Зәйнуллин

5) Яттан уку; хәтердәгесен бәян итү. *Ул әкиятне әгәр сөйләгәндә Чаглып китсә синең күләгән, Юк, юк, Мин ант итәм: Һичбер вакытта да Сине карак итеп сөйләмәм...* Һ.Такташ. *Авыл сәхнәсендә сезнең «Буй бәласе» дигән шигыregезне сөйләгәнем бар.* Б.Ислам

6) *күч.* Чагылдыру, күрсәтү, аңлату. *Археологик казу эшләре вакытында табылган таш киткәннәр, бөртек угычлар, эт һәм кәҗә сөякләре шул турыда сөйлиләр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

◊ **Сөйлә баштан, каләм каштан** Нәрсә хакында сөйләргә соң, дип аптырап әйтелгән сүзгә каршы әйтем. **Сөйләп торасы юк** Сөйләшкәндә әңгәмәдәшенең фикере белән тулысынча килешүне, хуплауны, куәтләүне белдерә. **Сөйләп торган була** *эрл.* 1) Кемне дә булса аклап яки акланып

сөйләүчегә карата әйтелә; 2) Үзе дә рәтләп белмәгән килеш нәрсәдер сөйләргә, аңлатырга маташкан кеше турында. **Сөйләр җире юк** Сөйләрлек сүзе-фикере, әйтерлек дәлиле, үзенең абруе булмау. **Сөйләр нәрсәсе юк** *к.* **сөйләр җире юк**. **Сөйлиләр тел талмасын дип** Юк-бар сөйләү турында. **Сөйлисе дә юк** *к.* **әйтәсе дә юк**. **Сөйлисең бармы** *к.* **сөйлисе дә юк**. **Сөйлисең бармы авызыңны шапылдатып** Инде мәгълүм нәрсәне, сүз куертып, сөйләп утыруга карата әйтелә

**Сөйләп алу** Тиз генә сөйләү. *Шул арада [Галиуллин] тозсыз анекдотларын да сөйләп алды.* Г.Кутуй. *Ул арада берничә күңелле мәзәк тә сөйләп алды Хәйдәр.* Ф.Яхин

**Сөйләп ату** Тиз арада барысын да сөйләү

**Сөйләп бару** Бер-бер артлы, рәттән сөйләү. *Шагыйрь, моңсулык агышына күңел кайнарлыгын ияртеп кенә, гадәти тормыш вакыйгаларын гүяки чәчеп-чәчеп җибәргәндәй итә дә җиңел адымлы тезмәдә сөйләп бара.* Ф.Яхин

**Сөйләп бетерү** Тулысынча, барысын да сөйләү; кирәген-кирәкмәгәнен сөйләү. *Ул --- Каргалы мулласының шул җирдән аерылгач акылыннан язып үлүен сөйләп бетерә дә, ахырда: – Менә шулай ул, иптәшләр ---, – дип тәмамлый.* А.Таһиров. *[Әсмабикә:] Сөйләп бетерсен әле, кызык бит. [Тәберде:] Таптыгыз кызык.* Ә.Баян

**Сөйләп бирү** Барысын да тоташтан, ачыктан-ачык сөйләү. *Туңган кулларын җылыта-җылыта, [Фатыйма] үз язмышын сөйләп бирде.* Г.Ибраһимов. *Башлап, Җиһанша карт эшнең авырлыгын, эш хакының азлыгын, ашаудан артмавын, эшчеләр эш хакы арттыруны сорарга үзләрен сайлаганнарын сөйләде. Сәгыйть белән егет тагын арттырыбрак сөйләп бирделәр.* А.Таһиров

**Сөйләп җибәрү** Уйламаганда, кинәт сөйли башлау. *Кара, кара, ничек кенә сөйләп җибәрә!* Т.Гыйззәт. *Сөйләп җибәр, булмаса, ялындырып торма.* Ф.Баттал

**Сөйләп йөрү** Һәрдаим, әледән-әле сөйләү. *Аны кешегә сөйләп йөреп булмый.* Г.Камал. *Тере калсам да, болай сөйләп йөрмәсләр иде, дигән кебек, миңа чирканып, ачуланып карый [Маһинур].* Г.Кутуй

**Сөйләп калу** Берәр вакыйгага кадәр сөйләп өлгерү. *Сөйләп калчы, Кабан, серләреңне... Йөзгән, диләр, синдә пароход.* Р.Вәлиев

**Сөйләп карау** Сөйләргә омтылу, тырышу; сынау өчен сөйләү. *Мин аңар [Сөләйман абзыйга], үземне таныштырып, аның гаиләсе белән моннан биш кенә ел әүвәл бик якын белеш булганлыгымны сөйләп карадым. Ул мине аңламады.* Ф.Әмирхан

**Сөйләп килү** Бернәрсәне дә калдырмыйча, барысын да билгеле бер вакытка кадәр эзлекле сөйләү. *Кияү бу сүзләрне бер оратор кебек янып, дәртләнеп сөйләп килде-килде дә ахырга таба хәлдән тайды ---.* Г.Ибраһимов

**Сөйләп китү** Сүз уңаенда, үз чиратында белән сөйләү; мавыгып, кызып, барысын да бер-бер артлы тезеп сөйләү. *– Сабактан соң эчәсе килер бит, – дип, дәрес арасында [Галиәкбәр абзый] үзенең тормышын сөйләп китте.* Г.Кутуй. *Сәмитова апа мине сөйләтә башлады. Ләкин бер җөмлә әйтү белән үк, хатамны тапты, менә болай ул, дип, үзе сөйләп китте.* Х.Камалов

**Сөйләп салу** Уйлаганын, күңелендә булганын турыдан-туры, ачыктан-ачык сөйләү. *Шул хәл турында сөйләп салганнан соң, Касыймнан сорап та куйган тагын, аның бу турыда нәрсә уйлавы турында.* Р.Гаязетдин

**Сөйләп ташлау** Кинәттән яки көтмәстән сөйләү; сөйләнергә тиеш булмаганын да сөйләү. *Диңгезчеләр ничектер очраклы рәвештә бер инглизгә төнге очрашу турында сөйләп ташлыйлар.* М.Мәһдиев. *Аның йөзе үзгәрүеннән шунда ук артыгын сөйләп ташлавымны аңлап алдым ---.* Ф.Яхин

**Сөйләп тору** Һәрдаим, әледән-әле сөйләү; хәзерге вакытта сөйләү. *Мин үзем дә юләр, миңа ни эшкә кирәк иде инде аңа театрга дип сөйләп торырга, мин аңа дәрес әйтәмме?* Г.Камал. *Әмма үзенең кем нигезендә утыруы турында бина үзе сөйләп тора: бөтен рәвеше, кыяфәте, кыйбла тарафка карап торышы белән.* Ф.Бәйрәмова

**Сөйләп узу** *к.* **сөйләп үтү**

**Сөйләп үтү** Ниндидер сөйләшүгә өстәп, сүз уңаеннан сөйләү. *Чәй янында сугыш турында сүз китте. Ахун Үзбәков элек булып үткән берничә сугышларны сөйләп үтте ---.* А.Таһиров. *Мин сезгә океан артындагы илләрнең берсендә ишеткән вакыйганы сөйләп үтмәк булам.* Ф.Баттал

**Сөйләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр эзлекле сөйләү. *Әлбинә артык киңәймичә һәм сузмыйча сөйләп чыккач, теге ягымлы елмаеп ым какты ---.* Казан утлары

**Сөйләп яту** Хәзерге моментта сөйләү, сөйләргә кирәк табу. *Кичен Искәндәр әнисенә сөйләп ятты: – Беренче урынны алсак, кая барырга?* М.Мәһдиев

**Сөйли бару** Рәттән, барысын да эзлекле сөйләү. *[Ченәкәй] Юл буена сөйли бара: – Мин сиңа өч кыз күзләп куйдым. Берсе – Кәримә Сабитова.* М.Җәлил. *Ул [Мөхәммәд пәйгамбәребез] аның һәр иңгән сүрәсен күңеленә сеңдерә барган, аннары халыкка җиткерә торган, соңрак аны телдән-телгә сөйли барганнар, мөридләре кәгазьгә төшергән.* Р.Вәлиев

**Сөйли башлау** Сөйләргә керешү. *Аннан соң ул, саташкан сымак итеп ---, кече атна көннәрендә кызы Әсманың өргә, кабереннән чыгып, тәрәзәләрне шакылдатып, ишегалдында йөргәнлеген сөйли башлады.* Ф.Әмирхан. *Мөхәммәтшин, --- җиңемнән өстерәп, әдәби бүлек бүлмәсенә алып кереп китте һәм анда миннән дә көчлерәк ярсыпташып сөйли башлады.* И.Салахов

**Сөйли бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйләүне дәвам итү. *Фагыйлә абыстай бу хакта ничә тапкыр уйлаганлыктан, тонык кына итеп сөйли бирде: – Кеше җибәртеп тә, болай да белештем.* Ф.Яхин

**Сөйли килү** Электән үк, эзлекле рәвештә барысын да сөйләү. *Аның [Һ.Такташның] байтак шигырьләрен мин еллар буе очрашуларда сәхнәдә торып сөйли киләм.* Р.Батулла

**Сөйли тору** Берәр хәлгә кадәр, күпмедер вакыт сөйләү. *Мин сөйли торам, кызның күзе моңаеп әсәрләнә.* Ф.Баттал.

*Карт беркемне дә тыңламады, һаман үзенекен сөйли торды*

**СӨЙЛӘҮЛЕК** *и. к.* **сөйләшмәлек**

**СӨЙЛӘҮЧЕ** *и.* 1) Нәрсәдер турында хәбәр итүче, әйтеп-сөйләп бирүче. *Сөйләүченең теле бик үткен булмаса да, вакыйгалар коточарлык иде.* М.Кәбиров. *Хат-мәктүп, сөйләүчеләр аша алар берберен бик яхшы белсәләр дә, ни гомер яшәп күрешкәннәре булмады.* Р.Батулла

2) Чыгыш ясаучы, сүз тотучы. *Хәзер инде Арча базарына да әйбер алырга дип түгел, күбесенчә эчтә кайнап торган ризасызлык белән борчуга җавап табарга, арбага менеп сөйләүчеләрне тыңлап, дөньяда ниләр барын, сугыш хәлләрен, җилләрнең кайсы яктан исүен белеп кайтырга дип баралар иде.* Г.Бәширов. *– Мөнә без, – дип дәвам итә сөйләүче, – икебез дә кандидатлык яклап чыктык.* К.Җәмитов

3) Яттан укучы; хәтердәгесен бәян итүче. *Бу өзекне дә ул һичшиксез безгә ятларга бирәчәк, икенче дәрестә, күзлеген кулында әйләндерә-әйләндерә, безне тыңлаячак, яхшы сөйләүчеләр булса, рәхәтләнүеннән: – Во! Во! Во! – дип торачак ---.* М.Мәһдиев

**СӨЙЛӘШ** *и.* 1) Сөйләшү, аралашу; сөйләм; сөйләнгән сүзләр. *Бер чит телне генә белгәндә, ул тел үз сөйләшебездә ана телебезне чүпли башлый ---.* Ф.Яхин

2) *лингв.* Тел диалектының аерым бер төбәккә, урынчылыкка хас төре, формасы. *Тарихи яктан шундый кызыклы сөйләш [нократ-глазов сөйләше] бүгенге көндә өлкән буын кешеләре өчен генә хас булып кала бара.* Ф.Баязитова. *Шуңа күрә мин мишәр диалектының минем игътибарны тарткан үзенчәлекләре, хәтта ул шивәнең үзенә генә хас авазлары, аһәңе, сүзләре хакында әйтә башлаган идем, Ринат, мине бүлдереп, үзенең шул сөйләш үзенчәлекләреннән ничек итеп көчкә котылуын сөйләп бирде.* Ю.Сафиуллин

**СӨЙЛӘШЕНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сөйләшү**. *Шуңа күрә кыз белән сөйләшенгән сүзләр тирәнгә керә алмый, су өстендә йөзеп йөргән май бөртекләре кебек өстә генә әйләнеп-тулганып торалар иде.* К.Тимбикова. *Фәнияр янында әнкәсе белән Фәүрия утыра. Аларның госпитальгә килгәннәренә инде дүртенче көн. Сөйләшер сүзләр сөйләшенгән.* Ф.Яруллин

2) Сүз куешылган, килешенгән булу. *– Эшләр шуңа ук барып җиттемени? – диде Муса, кашларын җыерып. – Саклык турында Рәхим белән сөйләшенгән иде бит.* Г.Әпсәләмов. *Ул арада, алдан сөйләшенгән буенча, ишектән Мәсрүрә килеп керде.* М.Мәһдиев. *Алдан сөйләшенгән, билгеләнгән пунктка вакытында килеп басмасаң, димәк, бер-бер хәл булган.* А.Хәсәнов

**СӨЙЛӘШМӘЛЕК** *и.* Чит телдә сөйләшүче белән аралашу өчен, гадәттә көнкүреш темаларына сөйләшү үрнәкләре һәм сүзлекчәсе булган ике яки күптелле белешмәлек; сөйләүлек. *Татарча-инглизчә сөйләшмәлек*

**СӨЙЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сөйләшү** (*1–3 мәгъ.*)

2) Сөйләшү мөмкинлеге бирү. *[Телефонга] кешеләр кереп, я Казан белән, я Самара белән, я Сембер белән сөйләштерүне таләп итәләр.* И.Гази

3) Сөйләтү, сөйләшергә этәрү, әңгәмәгә тарту. *Карчыклар аны [баланы] чакырып сөяләр, сөйләштерәләр.* Ф.Әмирхан

**Сөйләштерә башлау** Сөйләштерергә керешү. *Бу хакта Нәҗип укытучылар арасында гына түгел, укучылар алдында да ачыктан-ачык сөйләштерә башлаган иде.* А.Гыйләҗев. *– Бу кадәр калҗалар каян килә? – дип, юри генә, сүзне башлап китү өчен, боларны сөйләштерә башлаган.* Ф.Яхин

**Сөйләштереп алу** Беркадәр вакыт, бераз сөйләштерү; тиз генә сөйләштерү. *--- Каргалы юлына чыгып баручы олы гына яшьтәге ике хатынны туктаттым. Исәбем әзрәк сорашып, сөйләштереп алу иде.* Ә.Еники

**Сөйләштереп карау** Сынау максаты белән сөйләштерү. *Диләфрүз бик моңсу утыра иде, Гөлшаһидә сөйләштереп карагач та, күңеле ачылмады.* Г.Әпсәләмов. *Бер бик шәп кунак кыз килгән анда. Шуны сөйләштереп карарга исәп.* В.Нуруллин

**Сөйләштереп тору** Берәр хәл булганчы сөйләштерү. *Бер пәһлеван керде, аны күп сөйләштереп тормады, тәпәләде.* Казан утлары

**СӨЙЛӘШҮ** I *ф.* 1) Фикерне тел белән әйтеп бирә алу. *Моңа кадәр юньләп сөйләшә белмәгән бала, наркоздан соң күзен ачкач, компот сораган.* Өмет

2) Тумыштан билгеле тел бергәлегенә карау, билгеле бер телдә аралашкан халык вәкиле булу. *Һуннар берләшмәсендә төрки телдә сөйләшә торган кабиләләр була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

3) Берәр телне белү, аралашу максаты белән шул телдән файдалану. *[Рабига җиңгинең олы малае] --- ике елның берендә хатынын һәм үз ана телләрен ләм-мим белмәүче, әмма русча, немецча шытырдатып сөйләшүче ике кызын ияртеп, дөнья хәтле кучтәнәчләр төяп кайтып төшә дә ярты ай кунак булып китә...* Казан утлары

4) Берәү белән әңгәмә кору. *Кич белән кайсы ашый-эчә, кайсы балаларын йоклата, --- кайсылары җыелып утыралар да күргәннәрен-белгәннәрен сөйләшәләр.* А.Таһиров. *Узган ел Сабантуйда бер авыз сүз сөйләшеп булмады: шул күрше егете күзәтте. Кыз белән сөйләшү өчен мөмкинлекне тормыш үзе ясады.* М.Мәһдиев. *--- аны [Әлбинәне] һәр өйдә күптән көтелгән бер кунак рәвешендә каршы алдылар, ачылып һәм тәмләп сөйләштеләр, әйткән киңәшләрен, алтын сүзләр ишеткәндәй, бик хөрмәт белән колак салып тыңлап тордылар.* Казан утлары

5) Фикер алышу, киңәшләшү; килешү. *Казакъ кардәшләребез, сөйләшеп, киңәшеп, безнең арттан хәбәр бирәчәк булып калдылар.* Г.Исхакый. *Беренче пленумда совет язучылары социализм чоры әдәбиятының төп бурычлары турында сөйләштеләр.* М.Җәлил

6) Сүз куешу, килешү. *Кытай-япон сугышы үзеннән-үзе акрынлап суынды. Ул хәзер инде сөйләшү-килешү дәверенә керде.* Г.Исхакый. *[Асыл:] --- Гөлбизәк әни белән без хәзер иске йортка барырга сөйләштек.* Ә.Баян

**Сөйләшә башлау** Сөйләшергә керешү. *Мәсәлән, Уфа губернасындагы марилар, мәҗүси булып калган хәлдә, төрки-татар телендә сөйләшә*

*башлыйлар.* Г.Исхакый. *Стражниклар бер кәгазьгә, старостадан кул куйдыру урынына, сәнәк тамгасын куйдырып, Сәгыйтьләрне тапшырдылар да Мәһди белән сөйләшә башладылар.* А.Таһиров

**Сөйләшә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйләшүне дәвам итү

**Сөйләшә тору** Әлегә, хәзерге вакытта сөйләшү; берникадәр вакыт сөйләшү. *[Асыл:] Ләкин сиңа, Айбикә, ул канатсыз Шоңкарны ничек чакырып китермәвеңне исбат итәргә туры килүе бар. [Айбикә:] Канатлар хакында сөйләшми торыйк, Асыл.* Ә.Баян. *Сөйләшә торгач, камерага да, мәхбүсләргә дә ияләштем.* И.Салахов

**Сөйләшеп алу** Бераз гына сөйләшү. *Коридорда Билал Маһитап белән ни турындадыр пышылдап кына сөйләшеп алды.* А.Таһиров. *Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар.* Ә.Еники. *Ватиканда булган чакта, миңа Татарстан мөфтие белән сөйләшеп алырга кирәк булды ---.* Казан утлары

**Сөйләшеп бетерү** Ахырына кадәр, тулысынча сөйләшү; кирәген дә, кирәкмәсен дә сөйләшү. *Өйдән бераз киткәч тә, Сәрвәр җәйләүгә күчүләрен, анда туйлар булуын, бәйге ясауларын, --- яңгыр явып, тары, бодайларның уңуларын сөйләшеп бетергәч, артына карап алды* ---. А.Таһиров

**Сөйләшеп йөрү** Гел сөйләшү; озак вакыт сөйләшү алып бару

**Сөйләшеп калу** Сөйләшергә өлгерү

**Сөйләшеп карау** Сөйләшергә омтылыш ясау. *Туктале, әллә соң син сөйләшеп карыйсыңмы аның белән?* Н.Фәттах

**Сөйләшеп китү** *к.* **сөйләшә башлау**. *Фронттагы хәлләр турында сөйләшеп киттеләр [Гыйлаҗ белән Саттар].* А.Таһиров. *Чәй эчә-эчә сөйләшеп китәләр. Әкълимәттәй шунда чемодан турында сүз куша ---.* Казан утлары

**Сөйләшеп кую** Алдан ук сөйләшү. *Профессор белән алдан сөйләшеп куйган идек.* Г.Әпсәләмов

**Сөйләшеп тору** Әле, хәзер сөйләшү; һәрдаим аралашу. --- *Рәмисә Зәйнагов белән тегене-моны сөйләшеп торды да, капканы ябып, йортка таба атлады.* Казан утлары. *Балалар белән сөйләшеп торабыз*

**Сөйләшеп чыгу** Күпмедер вакытны тоташтан сөйләшеп үткәрү; барысын да сөйләшү. *Без төн буе синең турында сөйләшеп чыктык.* Г.Кутуй

**Сөйләшеп яту** Озак вакыт дәвамында сөйләшү. *Без шул көннәрдә яңа газит чыгару хакында сөйләшеп ятканга, мин Казаннан китә алмый идем.* Г.Исхакый

**СӨЙЛӘШҮ** II *и.* 1) Әңгәмә; аралашу, фикер алышу. *Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде шикелле ---.* Ә.Еники. *Ачык калдырылган бүлмә ишекләре аша кычкырып көлешүләр, кызып-кызып сөйләшүләр, бәхәсләр ишетелде.* Н.Фәттах

2) Телдән файдалану. *Татарның уңган-булган егетләре. Сөйләшүләре заманча: урысчалы-татарчалы.* Т.Миңнуллин

3) Нindидер бер максат белән очрашу; киңәшмә. *Безнең комиссиядә сөйләшүләр вакытында мәгариф министрыннан һәрвакыт «проблемалар бар, проблемалар бар» дип ишетеп киләбез.* Т.Миңнуллин. *Ә инде Вазих китәргә атна-ун көн генә калды дигәндә, алар арасында шактый ук үтемле җитди сөйләшү булып алды.* М.Хәсәнов

4) *күпл.* Нindидер мәсьәләләргә мөнәсәбәттә үзара килешү максаты белән очрашып фикер алышу. *Габдelгазиз Сәгалби безне тәкъдим итте, һәм сөйләшүләр башланды.* Г.Исхакый. *«Дини-милли идарә» тирәсенә оешкан карт бүреләрнең Уфа татар гаскәрен кара контр Дутов ягына чыгару турында яшерен сөйләшүләр алып барганлыгы мәгълүм булды.* Г.Ибраһимов

**СӨЙМӘН** *и.* Боз тишү өчен озын агач сапка утыртылган очлы тимер таяк

**СӨЙРӘГЕЧ** *и.* 1) Берәр авыр нәрсәне өстенә куеп, шудырып күчерү өчен зур чана рәвешендәге җайланма, стан

2) Гадәттә, тракторга тагып, тарттырып йөреп, юл өслеген тигезләү өчен авыр җайланма. *Ләкин урман эченнән сузылган киң юл чиста, аны трактор артына авыр сөйрәгечләр тагып тигезләткәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Кыш чыгарылган тирес өемнәрен таратуда рельслы сөйрәгечләрдән файдаланабыз.* Т.Нәҗмиев

**СӨЙРӘК** *и. к.* **сөйрәгеч**

**СӨЙРӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сөйрәү** (*1–5 мәгъ.*). *Өстән туплар очкан чак иде. Үлем баржалары сөйрәлгәндә, Дүрт иделнең өсте кан иде.* Ф.Кәрим

2) Өстерәлү. *[Айбикә:] Вакытлыча гына еланнар булып сөйрәлик тә, аннан соң аккошларга әйләнербез.* Ә.Баян. *Ат артыннан агач сөйрәлә.* Р.Батулла

3) *күч.* Авырлык белән генә, бик акрын, көчкә хәрәкәт итү. *Шәйхи эчкән; Шәйхи тәрәзәне ваткан, Урам буе исереп сөйрәлгән. Кем гаепле? Тукта!!! Кем төпкәрәк баткан?! Мәсьәләне карыйк тирәннән.* М.Җәлил. *Әнисе, ялгыз калган аккош тавышлары белән ачыргаланып, ихатага тикле сөйрәлеп чыккан иде дә, колга татар аның җиләненә ябышкан кулын чабып өзде.* В.Имамов. *Вәзир Солтангәрәй көчкә сөйрәлеп чыгып китә.* А.Гадел

4) *күч.* Башкалардан артка калу, артта булу. *Шәбрәк атлы, хәллерәк хуҗалар, ярлы-ябагай я начаррак ат артыннан барырга хурлана да, алга чыкмакчы була. Бүтәннәрнең дә, тузан йотып, артта сөйрәләселәре килми.* Г.Бәширов. *Нишлисең, укыган алга атлый, укымаган – сөйрәлә.* Туганайлар. *Ә бит ике ел элек иң арткы рәтләрдә генә сөйрәлә идегез.* Әгерҗе хәбәрләре

5) *күч. сөйл.* Әдәп-әхлак кануннарын исәпкә алмыйча, хатын-кызга яки ирләр-егетләргә бәйләнеп, алар артыннан йөрүче. *Бер генә дә оятың юк икән! Ир хакы димәдең, халыктан оялмадың, бер нәфесеңне тыя алмыйча сөйрәлеп йөрдең! Нинди тәүфикълы иреңне мыскыл иттең!* Г.Бәширов. *Кызлар артыннан сөйрәлеп, ятларга сатылып йөрмиләр аны…* Т.Гыйззәт

**Сөйрәлә башлау** Сөйрәлү хәленә күчү; сөйрәлергә тотыну

**Сөйрәлә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйрәлү

**Сөйрәлә килү** Күптәннән бирле сөйрәлү

**Сөйрәлеп бару** Сөйрәлгән хәлдә хәрәкәтләнүен дәвам итү. *Сөйрәлеп бара торгач, алда сизелер-сизелмәс кенә*

*ниндидер бер кара нокта күреп ала.* К.Җәмитов

**Сөйрәлеп йөрү** Озак вакыт, даими сөйрәлү. *Озак бит, былтырдан бирле сөйрәлеп йөри. Анысын да беләсез: ел буе авырды, акча эшли алмады.* Г.Бәширов. *Болай да инде минем аркада гына сөйрәлеп йөрдең!* Г.Каюмов. *Гаиләм булса, болай итеп авыллар буенча сөйрәлеп йөрер идеммени мин...* Аманулла

**Сөйрәлеп килү** *к.* **сөйрәлә килү**. *Болар [шайтан ялчылары] беренче [тамгалы коммунистлар] вә икенче [большевик өмәчеләре] бүлекнең койрыгында гына сөйрәлеп киләләр.* Г.Исхакый

**СӨЙРӘЛҮЧЕ** *с. зоол.* Сөйрәлүчеләр классыннан булган. *Еланнарның урман-кырларда көн иткәннәре дә күбесенчә тычканнар, бакалар, җирдән сөйрәлүче кош-кортлар белән тамак туйдыралар.* А.Хәсәнов

**СӨЙРӘЛҮЧЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Тәннәре мөгез кабырчыклар белән капланган, гәүдәләрен җирдән шудырып-сөйрәп яки үрмәләп хәрәкәт итә торган умырткалы хайваннар классы; рептилияләр (еланнар, кәлтәләр, крокодиллар, ташбакалар һ.б.). *Кичке чорларда, аеруча төннәрен, асфальт трассаларда юлны аркылы чыгарга теләгән рептилияләр, ягъни сөйрәлүчеләр, еланнар хисапсыз һәлак булалар икән.* А.Хәсәнов. *Кәлтә, елан кебек сөйрәлүчеләрнең тәне – тиреле япма, крокодил һәм ташбакаларныкы известь кабырчык белән капланган.* Т.Шакирова

**СӨЙРӘЛЧЕК** *с* **1.** 1) Бик әкрен, атлар-атламас, һаман артта калып, сөйрәлеп, өстерәлеп йөри торган

2) Сөйрәлеп бара торган; сөйрәп алып барыла торган. *Сөйрәлчек йөк*

3) *сөйл.* Хатын-кыз яки ир-атка бәйләнеп, аңа сөйкәлергә (*3 мәгъ.*) маташучы, аның артыннан йөрергә, сөйрәлергә (*4 мәгъ.*) яратучы

**2.** *и. гади* Хатын-кызга бәйләнеп, аның артыннан йөрергә, сөйрәлергә (*4 мәгъ.*) яратучы ир яки ир-ат артыннан калмый йөрүче, сөйрәлүче хатын. *– Нинди сөйрәлчек янында йөрдең кичә? – диде [Роза] һәм, тыелып тора алмыйча, тагын тавышсыз гына елап җибәрде.* В.Нуруллин. *[Рафаэль, кызып:] Ризидә – сөйрәлчек, бозык, пычрак, шлюха!* З.Хәким

**СӨЙРӘТКЕ** *и. к.* **сөйрәткеч**

**СӨЙРӘТКЕЧ** *и.* Печән, салам һ.б.ш.ны кибән, эскерт салына торган җиргә яки башка урынга җыйганда кулланыла торган тарттыру җайланмасы; чүмәлә тарттыргыч. *Сөйрәткечләргә печән өя башладык. Нәнирәкләр, тезген тотып, печәнне болын уртасынарак – бер биек кибән куелачак урынгарак тарттыра.* Г.Хәсәнов. *Шуларны күреп йөргән малай да үзен гел олыларча тотты: орлык тутырганда, агулы дип тормады, капчык авызына ябышты, атлы сөйрәткеч белән салам тарттырды ---.* Кызыл таң

**СӨЙРӘТТЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **сөйрәтү**. *Дүрт баш сарыкның авызларын бисмилла тастымаллары белән уратып, мекердәтми-мөгрәтмичә генә, тыннары каткан алмагачлар аша мунча артына сөйрәттереп, берсе арты берсен чала, Гарифулла исә туный торды.* А.Хәлим

**СӨЙРӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сөйрәү** (*1, 2 мәгъ.*). *[Бай – хезмәтчеләре турында:] Әгәр берсе каршы килеп җавап бирсә, урамга сөйрәтәм дә тиз ташлатам.* М.Гафури

2) Өстерәтеп, тарттырып, башка урынга күчерү. *Озакка сузмый, үз нигезебезгә бик шәп йорт салырга кирәк. Аны Селәгәйләр трактор белән сөйрәтеп алып китә алмас.* Ф.Яруллин. *Иң гаҗәбе шунда: машинаны бүген сөйрәтеп алып кайтып ташлыйсың, иртән берни булмагандай кабына да китә.* Ф.Садриев. *Күп тә үтмәде, сука калагына охшаган мөгезләре белән җирне сөрдереп, тау кадәрле ике пошины сөйрәтеп ачыклыкка чыгардылар.* Х.Мәхмүт

3) Өстерәү, идәннән, җирдән аермыйча тартып бару. *Ләкин ул арада Яруллин дигәннәре, арткы чанадан төшеп, бөкрәеп һәм толып чабуларын җирдән сөйрәтеп, үзе Зөфәр янына килде.* Ә.Еники. *Янә катлы-катлы озын күлмәген җирдән сөйрәтеп килгән чегән киләчәген юрамакчы булды.* Ф.Җамалетдинова

4) *диал.* Сөйрәү (*3 мәгъ.*), лаштырдату. *Тиздән, катасын кыптыр-каптыр сөйрәтеп, Гайнулла килде.* Т.Гарипова

**Сөйрәтә бару** Бер-бер артлы, барысын да рәттән сөйрәтү

**Сөйрәтә башлау** Сөйрәтүгә керешү

**Сөйрәтә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйрәтү

**Сөйрәтеп йөрү** Һәрвакыт, озак вакыт сөйрәтү

**Сөйрәтеп ташлау** Кинәт, көтмәстән, тиз арада сөйрәтү

**Сөйрәтеп тору** Бертуктаусыз, әледән-әле яки хәзерге вакытта сөйрәтү белән мәшгуль булу

**Сөйрәтеп чыгу** Һәрберсен, булган берсен сөйрәтү; барысын да берәмберәм сөйрәтү

**СӨЙРӘҮ** *ф.* 1) Күтәрми генә тартып бару; өстерәү; ниндидер өслектән шудыру. *Кулындагы камчысын сөйрәп килде дә, учак янына җиткәч, чирәмгә ауды [Сәлмән].* Г.Бәширов. *Гитлерчылар мәетне аягыннан сөйрәп алып чыгып киткәч, Назимов көч-хәл белән генә торып утырды.* Г.Әпсәләмов. *Суда тыпырчынган Хәтимәне кызлар яр кырыена сөйрәп чыгардылар.* Н.Гыйматдинова

2) Ихтыярына каршы, ирексезләп, көчләп алып бару. *Үзен каядыр сөйрәүләрен Владимир күрми дә, сизми дә иде.* Г.Әпсәләмов. *Хәмит тә мине сөйри башлаган иде, ләкин минем бу көрәшнең ахыры ни белән беткәнен күрәсем килде.* Ф.Яруллин. *Рәйсә ханым Мортазинны, кулыннан сөйрәп диярлек, корпус ишегенә таба алып китте.* В.Имамов

3) Көч-хәл, авырлык белән, аякларны күтәрмичә, өстерәбрәк атлау. *[Әбинең] --- күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри...* Ә.Еники. *Күбесе [атлар], аякларын көч-хәл белән сөйрәп, кичен абзарга кайталар.* В.Имамов. *Ул әле дә исән, арт санын сөйрәп, балаларга тагылып йөри.* И.Нәбиуллина

4) Күтәрү, асып йөртү (авыр нәрсә тур.). *Көянтәләр җырда калыр инде, Хыяллардан читкә кителгән. Китапдәфтәр төяп, сумка сөйрәп Йөрим асылмалы күпердән.* К.Булатова

5) Тагып, тарттырып, җигелеп алып бару. *Кара бия арбаны көчкә генә сөйрәп менә.* Г.Бәширов. *Агач тырмалар (станы агач, тешләре тимер) инде бетеп бара, --- тракторлар җир сөргәндә яки --- «Коммунар» исемле иләмсез зур комбайн агрегатларын сөйрәп йөргәндә, бу «зигзаг»ларны безгә биреп торалар.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Ошатмый, яратмый гына, кадерсезләп киеп яки өскә элеп, күтәреп йөрү. *Көн дә яңгыр, көн дә кожан сөйрә, әллә ничек – тышта күңелсез.* Ш.Мөдәррис

7) *күч.* Кирәгеннән тыш зур үлчәмле, җайсыз-ипсез булганлыктан, өстерәп, шудырып бару (аяк киеме тур.). *Аннары, артсыз башмакларын чаштыр-чоштыр сөйрәп, ишеккә юнәлде.* М.Маликова. *Бераздан әбисенең олы, очлы башлы галушларын сөйрәп, Фәрит килеп тә чыкты.* И.Диндаров

8) *күч.* Бернәрсәгә карамастан алып бару, башкару (авыр эш, тормыш һ.б. тур.). *Егылам-егылам дип торган шушы чирле хуҗалыкны ничек кенә булса да аудармыйча сөйрәп бару хәзер әни өстендә иде.* Г.Бәширов. *Хәлим --- иртәнге таңнан алып кара төнгә кадәр эшләде, бөтен хуҗалыкны үз җилкәсендә сөйрәп барды.* Г.Гыйльманов

9) *күч.* Теләк яки ихтыярга каршы кая да булса барырга, кая да булса булырга мәҗбүр итү, ирексезләү

10) Берәр эш-гамәлне тоткарлау; начар тәэсир итү. *Менә шушы куркаклык безне артка сөйри дә инде.* Ф.Яруллин. *Заманыбызның авыр бер мәсьәләсен – кешелекне упкынга сөйрәүче эчкечелек чирен ярып күрсәтүе белән повесть соңгы еллар татар әдәбиятында яңа бер сүз булды.* А.Әхмәдуллин. *Берәүләрне җәһәннәмгә сөйри нужа, Һәркемгә үзенеке, Ә берәүләр тиенәләр җәннәт сыена.* Л.Шагыйрьҗан

**Сөйри башлау** Сөйрәргә totыну. *Менә шәкерт малайлар мәдрәсә белән ике арада шакы-шокы агач башмак сөйри башлый ---.* Г.Бәширов. *Куркуыннан акылдан язарлык дәрәҗәгә җиткән Айсылу хәлсез кала, аны җен, кулыннан җилтерәтеп алып, үзе артыннан сөйри башлый.* А.Гадел

**Сөйри бирү** Бернәрсәгә карамастан сөйрәүне дәвам итү. *Җиңелүчеләр, үкчәләре белән яшел чирәмне тырныйтырный, бирешмәскә тырышалар, ә җиңүчеләр, аякларын терәп, җанфәрман сөйри бирәләр.* Ф.Яруллин. *[Мәрмәрис] гаилә арбасын тартәгә типмичә генә сөйри бирде.* Д.Гыйсметдин

**Сөйри тору** Берәр хәл булганчы сөйрәү

**СӨЙРӘҮЛЕК** *и.* Бер-берсеннән ерак булмаган ике сулык арасындагы коры җир, субүләр; суднолар сөйрәп күчерелгән урын

**СӨЙРЕ** *и. зоол.* Озын аяклы черки

**СӨЙРЕК** *и. зоол.* Мәрсинчәләр семьялыгыннан төче суларда яшәүче уксыман башлы эре балык; укбаш, чукыр, севрюга

**СӨЙРЕ ЧЕБЕН** *и. зоол.* Канечкеч чебен

**СӨКӘ** *и.* Эчкә таба очлаеп кереп торган тар авызлы итеп озын чыбыктан үргән балык аулау коралы, тозагы. *Безнең Укмас суын беләсез: балыкка дип куйган сөкәләр була анда.* Ф.Хөсни. *Бабай, сөкә бавын чишеп, кәрәкәләрне суга җибәрде.* Р.Батулла

**СӨКӘЛЕК** *с.* **1.** Сөкә үрү өчен билгеләнгән яки шуңа ярарлык, җитәрлек булган. *Сөкәлек чыбык әзерләп кую*

**2.** *и. мәгъ.* Сөкә үрү өчен билгеләнгән яки шуңа ярарлык, җитәрлек булган материал

**СӨКӘТ** *и.* Берәр кош яки хайван рәвешенә китереп, төгәл итеп шуны кабатлаган, шуның тиресе эченә салам, мамык һ.б.ш. әйберләр тутырып ясалган сын

**СӨЛӘЙМА́Н БАЛЫГЫ** *и. зоол.* Сөләйман балыгысыманнар отрядыннан, төче суда яши торган кызгылт яисә алсу итле, кыйммәтле промысел балыгы; *русчасы:* **лосось**. *Сөләйман балыклары, меңләгән төркемнәргә җыелып, елга тамагына килделәр.* Р.Батулла. *Ә сөләйман балыклар, уылдык чәчү вакытында, зур-зур көтүләргә җыелып, елга һәм елгачыкларга юнәләләр ---.* Биология

**СӨЛГЕ** *и.* Сөртенү өчен махсус сугылган яки кисеп тегелгән, төрле зурлыктагы, гадәттә, озынча тукыма кисәгеннән гыйбарәт әйбер. – *Чибәр егет бүләк сорый, Ни бирием, әнкәем? – Үзең тукып, чүпләү салган Сөлгеңне бир, бәпкәем.* Җыр. *[Гәрәй] --- үлекнең янына килде, кулларын иләп куйды, башын рәтләде, күз кабакларын йомдырды, йөзенә, күкрәгенә өйдә булган актык кызыл сөлгене ябып куйды.* Г.Ибраһимов

**СӨЛГЕЛЕК** *с.* 1) Сөлге сугу яки кисеп тегү өчен билгеләнгән, шуңа ярарлык, җитәрлек булган. *Сөлгелек тукымага басма бизәкләр төшерү*

2) *и. мәгъ.* Сөлгегә ярарлык яисә җитәрлек материал. *Базардан сөлгелек сатып алу*

**СӨЛЕК** *и.* 1) Кеше яки хайван тәненә ябышып, аларның канын суырып яши торган төче су суалчаны. *Рәтен белеп алгач, чаңгыда баруның бер авырлыгы юк аның. Сөлек урынына шуып кына барасың.* В.Нуруллин. *Сөлекләрнең күпчелеге – төче су организмнары.* Биология

2) *күч.* Төз гәүдәле, зифа буйлы, ыспай кыяфәтле кеше. – *Нинди нечкәргән! Корсак ничек җыелып килгән! – Әйе, сөлек тә сөлек, бу да сөлек инде!* Г.Бәширов. *Кайчандыр, бик күптән инде, ул [Миңлебай карт] үзе ир-егет чагында, камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып, далага чыгып китә иде ---.* Ә.Еники

◊ **Сөлек кебек** 1) Төз, зифа буйлы, ыспай. *Утыз яшьләр чамасындагы хуҗа хатын сөлек кебек таза, чибәр Галиуллага күзләрен сирпеп-сирпеп карап, аның каршында бөтерелә башлады.* З.Зәйнуллин. *Хәрби уку йортын тәмамлавына, [Гарифҗан] Казанның сөлек кебек кызы белән туй ясады.* Ф.Яхин; 2) Төз, зифа гәүдәле, пропорцияләре дөрес булган (ат һ.б.ш. хайван тур.). *[Иркәбай:] Сәгыйть, сезнең дә бит кола биягез колынлаган иде. Шундый матур, сөлек кебек тере айгыр колын иде, соклангыч иде.* А.Таһиров; 3) Паразит кебек, ерткычларча; әрсез. *Ул алыпсатарлар кеше канына сөлек кебек ябышканнар, күбенүләре җиткән...* Н.Хәсәнов. **Сөлек сыман**

*к.* **сөлек кебек**. **Сөлек урынына иму** Башка берәү хисабына көн күрү, аның көченнән файдалану

**СӨЛЕКЧЕ** *и.* Сөлек салучы, шундый эш белән шөгыльләнүче. *Әби тирә-якта данлыклы сөлекче иде, Чулпан да сөлек сала, куллары бик шифалы.* Ватаным Татарстан. --- *бер кочак авырулар белән Балтачтан сөлекче Зөлфия ханымны эзләп таптым.* Безнең гәҗит

**СӨЛЕС** *и. гар.* Гарәп каллиграфиясендә хәрефләрне йомры итеп һәм үреп язу рәвеше. *Куфи һәм сөлес язулары белән язучы осталарыбыз бар; бәгъзе назым белән язучы шагыйрьләребез бар.* Г.Гобәйдуллин. *Ташлардагы язмалар гарәпнең сөлес һәм тәгълиқъ ысулларында эшләнгәннәр.* М.Әхмәтҗанов

**СӨЛТӘР** *и. монг.* 1) Скелет. *Йолык кылынган йолдыз-кашканы итеннән-тиресеннән, эчәк-бавырыннан арындыргач, шәрә сөлтәрне иплән кенә аягына бастырдылар, ычкынырга гына торган сөякләрен бер-берсенә бәйләп куйдылар.* Н.Фәттах. *Беренчедән, аның ташбилгесе һәм сөлтәре яхшы сакланган булган...* А.Тимергалин

2) Нәрсәнең дә булса нык нигезе, таяну өлеше, каркасы

3) Калдык-постык; сөяк-санак калдыклары

4) *миф.* Скелетсыман өрәк; карачкы; күләгә, шәүлә

**СӨЛТЕК** *и. к.* **сөлтәр**. *Сездән сөлтекләрдән Курка торган Идегәй юк!* Дастан

**СӨМ** *и. фин-угор* 1) Биш тойгының берсе булган капшап тою, тактиль сизем. *Танышыма шуннан артык игътибар итә һәм бәя куя алмадым, чөнки сөм тоймый башлаган уч төпләремә җан керүне сизүдән дә рәхәтрәк нәрсә юк иде минем өчен бу минутларда.* Ф.Садриев

2) *күч.* Мән, такт; әдәплелек

**СӨМБАШ** *и.* 1) *зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан озынча, ян якларыннан кысык, көмешсыман вак тәңкәләр белән капланган гәүдәле, алсу итле, кыйммәтле промысел балыгы; *русчасы*: **сёмга**. *Шуны да белеп торыгыз: Норвегиядән китерелә торган сөмбаш (сёмга) сулыклардагы кечкенә генә ябык махсус корылмаларда үрчетелә.* Ватаным Татарстан

2) Шул балыкның ите. *Кызыл балык: сөмбаш һәм сөләйман балыгы нерв системасын ныгыта.* Шәһри Казан. *Базарда сатып алган сөмбаш (сёмга) балыгын юган су кып-кызыл төскә керде.* Кызыл таң

**СӨМБӘ** *и. диал.* Мылтык һ.б.ш. утлы корал көпшәсен чистарта һәм майлый торган саплы тимер чыбык; шомпол

**СӨМБЕЛ** *и. гар.* 1) *бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан хуш исле, кыңгырау сыманрак вак-вак чәчәкле, суганчалы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **гиацинт**

2) Бөдрә чәч, көдрә чәч

**СӨМБЕЛӘ** *и.* 1) *астр.* Зодиак поясына керә торган йолдызлык атамасы. *Ә туй көзгә кергәч, Сөмбелә йолдызлыгында узачак, Алсу туган айда.* Сөембикә

2) Шул йолдызлыкның тамгасы; Кыз йолдызлыгы

3) *иск.* Хәзерге календарь буенча 22 августтан 21 сентябрьга кадәрге вакыт аралыгы; ай исеме. *Сөмбеләдә урып ал, арышыңны чәчеп кал*

4) Сөмбелә бәйрәмендә көз образын гәүдәләндерүче кыз

5) *шигъ.* Сары чәчле, чибәр, сүзгә оста, җор телле кыз

◊ **Сөмбелә бәйрәме (көне)** Көзен, гадәттә сентябрьнең егермеләрендә үткәрелә торган уңыш бәйрәме; бәйрәм итүнең бер йоласы кыз димләү гадәте белән дә тыгыз бәйләнгән. *Халкыбызның гореф-гадәтләренә нигезләнгән «Аулак өй», «Сөмбелә» бәйрәмнәрен үткәрү матур гадәткә керде*

**СӨМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Капшап тою, сизү сәләте нык кимегән яки югалган; оеган; хәлсезләнгән. *Мусаның сөмсез аяклары җирдән бөтенләй сөйрәлеп бара иде инде.* Ш.Маннур

2) Күңелсез, төшенке. *Карчык юл буе үзен урап килгән сөмсез, караңгы уйларыннан арына алмый иде булса кирәк ---.* А.Гыйләҗев. *Авыл --- икенче яктан көенде: чандыр гәүдәле сөмсез малай гел үги әтисен хәтерләтә, аның күзләре сәер ялтырый, көлемсерәп кенә сөйләшүләре бик астыртын икәнлегенә ишарә төсле иде.* Н.Гыйматдинова

3) Тупас, дорфа; тәрбиясез, әдәпсез. *Алай-болай сөмсез сыер урынына күзләре акайган дошман килә башласа, Фәрухша бу ике хәрби коралдан ут ачачак.* С.Поварисов

**2.** *рәв. мәгъ.* Әдәпсез, тупас, дорфа рәвештә, оятсызларча. *Җим өстенә менеп тибенгән тавык кебек сөмсез кыйланулар һич ярамый безгә.* В.Имамов

**3.** *и. мәгъ.* Тупас, дорфа, әдәпсез кеше. *Кемнең нәрсәсе юк: азгын кызның кызлыгы юк, бозык хатынның намусы юк, сөмсезнең вөҗданы юк, телсезнең өне юк.* Г.Хөсәенов

**СӨМСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Капшап тою сәләте нык кимү яки тулысынча бетү; хәлсезләнү. *Баштарак Арслан аны култыклап барды. Ләкин Муса аякларының сөмсезләнүе тагын да көчәю сәбәпле, олы гәүдәле Арсланның да аны әйдәргә көче җитмәс булды.* Ш.Маннур

2) Тупас кылану, дорфалану, әдәпсезләнү; мәнсезлек күрсәтү. *Син, егет, бик сөмсезләнәсең. Сине бераздан кире армиягә переподготовкага җибәрергә кирәк булыр, ахрысы.* З.Хәким. *Бу мәсьәләдә ничек тә сөмсезләнмәскә кирәк. Сөмсезләнмик, җәмәгать!* Кызыл таң

**Сөмсезләнә бару** Торган саен ныграк сөмсезләнү

**Сөмсезләнә башлау** Сөмсезләнергә тотыну

**Сөмсезләнә төшү** Бераз сөмсезләнү; тагы да сөмсезләнү

**Сөмсезләнеп китү** Ниндидер сәбәптән сөмсезләнү

**Сөмсезләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта яки һәрвакыт сөмсезләнү. *Кулларым да сөмсезләнеп тора кебек.* Л.Зөлкарнәй

**СӨМСЕЗЛЕК** *и.* 1) Хәлсезлек, оешканлык, тою сәләте булмау күренеше. *Малайның бу көтелмәгән хәбәрдән тирә-ягы чайкалып китте, тез буыннарында ниндидер сөмсезлек тоеп, урындыкка лып итеп утырырга мәҗбүр булды.* Ш.Маннур

2) Тупаслык, дорфалык, тәрбиясезлек, әдәпсезлек. *Аларга, башкасы*

*бирелмәсә дә, сөмсезлек Ходай тарафыннан чиксез күп бирелгән.* Н.Нәҗми. *Ирнең кыяфәтендә артист Крамаровка хас сөмсезлек, оятсыз үҗәтлек күреп, ул [Григорий] тагын пошаманга калды. Уңамы, әллә туңамы?* А.Хәлим

**СӨМСЕР** *и. иск.* Сәламәт рух; күтәренке күңел

◊ **Сөмсере коелу** Нәрсәдән дә булса кәефсезләнү, күңелсезләнеп йөз караңгылану; кәеф кырылу. *Шуннан мин сөмсерем коелып кайтып киттем дә үзебезнең колхозда көндез бригадир ярдәмчесе --- булып эшли башладым.* В.Нуруллин. *Алар беренче очрашудагы урында, теләксез эскәмиядә утырганда, Фәрхунә, сөмсере коелып: – Август беткәндә генә күрешәчәкбез икән, – диде.* М.Хуҗин

**СӨН** *и. тар.* Безнең эрага кадәр Үзәк Азия далаларында яшәгән һәм төркиләрнең борынгы бабалары дип фаразланган күчмә халык. *Кимендә III гасырдан башлап безнең эраның III– IV гасырларына кадәр «сөн» дигән күчмә халыклар яшәгән.* Н.Фәттах. *Кытайлар исә сөн императорын үзләренчә «шаньюй» дип атап йөртәләр.* С.Шәмси

**СӨННӘТ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзенең сүзләре, эшгамәлләре яки сахабәләренең ул яхшы күргән эш-гамәлләре; шулар турында хәдисләр формасында сакланган җыйма мәгълүмат; ислам хокукында Коръәннән кала икенче чыганак. *Дини эшләрдә төп канун Коръән Кәрим һәм Рәсүлүллаһның сөннәте.* Р.Фәхретдин. *Коръән вә сөннәттә музыка коралында уйнау вә уен тавышларын тыңлау харам булу хакында ачык бәян ителгән сүз юк.* А.Тимергалин

2) *дини* Мөхәммәд пәйгамбәрнең фарыз һәм вәҗибтан кала кылган һәр гамәле; шәригать хөкемнәре арасында мөселманнар өчен кылынуы яхшы күрелгән, кылынмавы хупланмаган эш, гамәл. *– Сабах намазының ике рәкәгать сөннәтен һәм фарызын укыячакбыз... – диде бала.* А.Хәлим. *Ләкин нәрсәнең фарыз, нәрсәнең сөннәт икәнлеген белер яшькә дә җиткәнбез инде!* Н.Кәримова

3) Ир балада ирлек әгъзасының башын каплап торган ярыны кисеп алу гамәле. *Сөннәтнең бәясе, күз җиткәч, бер каз икән.* М.Мәһдиев

4) Сөннәткә утырту йоласы. *Кемнеңдер сөннәтенә күчтәнәч алып килү*

**2.** *с. мәгъ.* Шәригатьтә мәҗбүри (фарыз яки вәҗиб) булмаган, ләкин үтәлүенә өндәлгән, үтәлмәве хупланмаган (эш-гамәл, гадәт тур.). *Мөселманнарның бер-берсе белән очрашкан вакытта сәлам бирешүләре сөннәт гамәл булып, һәр ике тараф берьюлы бирсә, шуның белән сөннәт үтәлгән була.* Р.Фәхретдин. *Мәчеткә барганда, бер юлдан барып, кайтканда, икенче юлдан кайту шулай ук сөннәт хәлдер.* Дога китабы

**3.** *хәб. функ.* Шәригатьтә үтәлмәве яхшы күрелмәгән, үтәлүе хупланган эш-гамәл турында. *Тозны аштан элек кабаргамы, соң кабаргамы? Әллә элек тә, соң да кабу сөннәтме? Бер төрлесе, элек кабу сөннәт, дисә, икенчеләре, аштан соң кабу фарыз, дип ныкыышты.* М.Галәү. *– Садака бирү һәм алу фарызмы, сөннәтме? – дигән сорауны бирде [Шәпеш хәлфә].* Ә.Фәйзи

◊ **Сөннәткә бирү** *к.* **сөннәткә утырту**. *Сөннәткә бирү йоласы татарларда һәм башка төрки халыкларда әле дә кулланыла.* Н.Фәттах. **Сөннәткә утырту** Ир баланың (кайчакта җиткән егетнең) сөннәтлеген кисеп алу. *Кара әле, абыстай, сөннәткә утыртасы балаларыгыз булса, киләсе елга мин килгәнче бирми торыгыз, мин абызателне килермен.* Т.Гыйззәт. *Гөлмәрьям апа бервакыт ике улын берьюлы сөннәткә утыртты.* Ф.Яруллин

**СӨННӘТЛӘ́Ү** I *ф. дини* 1) Сөннәткә утырту, сөннәтле итү. *Авылга кызлар сөннәтли торган баба килгән бит!* Т.Гарипова. *Төрек солтаннары яу сәфәре вакытында чит илдәге бәп-бәләкәй малайларны да әсирлеккә җыя, Төркиягә алып кайткач, аларны сөннәтләп, ислам диненә иңдерә ---.* В.Имамов

2) Сөннәт (*2 мәгъ.*) шартларына туры китереп башкару. *Алайса, картымны сөннәтләп җирләгез, түлке, зинһар, җир өстендә калдырмагыз, дип ялынгач, мулла абзый рөхсәт иткән.* Р.Батулла

3) *күч.* Кисү, кыскарту, киметү. *Конституцияне Мәскәү кушканча сөннәтләү, суверенитетны кырып-себереп түгү турында бер сүз дә әйтелмәде.* Р.Вәли

**Сөннәтләп йөрү** Әле, хәзер сөннәтләү: даими, һәрвакыт сөннәтләү

**Сөннәтләп бетерү** Сөннәтләүне тәмамлау; берсен дә калдырмый сөннәтләү

**Сөннәтләп кую** Көтмәгәндә, тиз арада сөннәтләү. *Ул арада дәү әтием белән әлеге карт мине шалт төртеп аудардылар да, шалт мөхәммәтҗан, сөннәтләп тә куйдылар.* А.Хәсәнов

**Сөннәтләп чыгу** Барысын да рәттән сөннәтләү

**Сөннәтли башлау** Сөннәтләргә тотыну

**СӨННӘТЛӘ́Ү** II *и.* Сөннәткә утырту йоласы. *Сөннәтләү дә – пәйгамбәребез кушкан эш.* Татар әдәбияты. *Барлык сәламәтлек саклау оешмасы да сөннәтләүгә алынырга җөрьәт итми.* Ватаным Татарстан

**СӨННӘТЛЕ** *с.* 1) Сөннәткә утыртылган. *Шикләнмәсеннәр: Аллага шөкер, кисәсе бер киселгән инде – сөннәтле.* Ә.Гаффар. *[Мөзәянә:] --- Кара әле, кызым Заһидә, Мирвәли мәрхүм сөннәтле идеме? [Заһидә:] Анын сөннәте белән нишлисең? Кияүгә чыгарга уйламыйсыңдыр бит?!* Казан утлары

2) Борыны балдаклы итеп эшләнгән (комган тур.)

3) *иск.* Камалы, кырпулы. *Сәхәби сөннәтле бүреген салып чөйгә элеп куйды һәм, кесәсеннән чыгарып, башына искергән кызыл фәс алып киде.* Ә.Фәйзи. *Крәстиян башы, Печән базары агайларының башлары кебек, сөннәтле бүрек кияр өчен генә түгел шул.* К.Әмири

**СӨННӘТЛЕК** *и.* **1.** Ирлек әгъзасының башын каплап тора торган яры. *Ир-балаларның, ир-атларның тышкы җенси әгъзаларының башын каплап торган тире, медицина теле белән әйткәндә, җенес органы каплавычы яки сөннәтлек дип атала.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Сөннәткә **1.** (*4 мәгъ.*) утыртылырга тиешле. *Үткән ел бай ел булганга, сөннәтлек малай күп иде.* Г.Исхакый

**СӨННӘТСЕЗ** *с.* 1) Сөннәте (*3 мәгъ.*) булмаган, сөннәткә утыртылмаган

2) Кырпусыз, алдан батырып, күзгә чаклы төшереп киелә торган (малахай, бүрек тур.). *[Некрутлар] сөннәтсез бүрекләрен кырын салганнар, билләренә кызыл, сары билбау бәйләгәннәр.* А.Таһиров. --- *Мостайның күзләре май ашаган мәченеке кебек ялтырый, мыек чылгыйлары тиен койрыгы кебек үрә утырган, башындагы сөннәтсез бүреген кыңгыр салган, – кияү егете диярсең...* Г.Әпсәләмов

3) Борыны балдаксыз итеп эшләнгән (комган тур.)

**СӨННӘТ ТУЕ** *и.* Ир баланың сөннәте уңаеннан үткәрелә торган мәҗлес. *Кадерле атаның, ананың бердәнбер углының сөннәт туена Әстерхан нугае ни дәрәҗәдә игътибар берлән хәзерләнсә, бөтен милләт үз матбугатының шул туена шулкадәр әһәмият берлән хәзерләнәдер.* Г.Исхакый. *Аерым тантаналарда – илгә илчеләр килгән чакларда, бәбәй туе, сөннәт туе яки сөекле якыныңның олуг сөенече булган көннәрдә генә яндыра торган биш йөз шәмле кандилне, түшәмнән төшереп, биш йөз янулы шәм утыртып, янә түшәмгә күтәртеп куйдылар.* Р.Батулла

**СӨННӘТЧЕ** *и.* Сөннәткә (*3 мәгъ.*) утыртучы. *Мүкәләсә мүкәләр, иртә сөннәтләү тиеш, дип, бу эшкә Масра авылыннан атаклы сөннәтче Әсхәбетдин бабаны чакыралар.* Р.Батулла

**СӨННИ** *с. гар.* **1.** Сөннәткә (*1 мәгъ.*) нигезләнгән; сөннилек белән бәйле булган. *Хәнәфиләр безнең илдәге сөнни мөселманнарның күпчелеген тәшкил итә.* Фән һәм тел. *Үз-үзләрен кыйнап, матәм барган шигыйларны күргән бер сөнни шәкерт аларга карата каһәр сүзләре ычкындыра.* Гасырлар авазы

**2.** *и. мәгъ.* Ислам диненең сөннилек тармагын тоткан кеше. *Сезнең мәмләкәттәге ярты диндар – сөнни, ә калганы – шигый.* В.Имамов. *Иң кыены шул булды: Болгар йортына ислам ике яклап һәм төрле вакытларда килеп кергәнгә, бирүдә сөнни мәзһәбеннән тыш шигыйлык шаукымы да сизелә иде.* А.Тимергалин

**СӨННИЛЕК** *и. дини* Ислам диненең Коръәнгә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең сөннәтенә нигезләнеп гамәл кылуны бердәнбер һәм иң дөрес юл дип санаган хәнәфи, малики, шафигый һәм хәнбәли мәзһәбләреннән торган юнәлеше

**СӨ́НЧӘ** *рәв.* Сөннәр телендә. *Ул үзенең шулкадәр күп сөйләп ташлавын, җитмәсә, сөнчә аңламаган кешегә сөйләп ташлавын чамалап, кинәт тынып калды.* Н.Фәттах

**СӨҢГЕ** *и.* 1) Озын, гадәттә агач сабының бер башына тимер очлык кертелгән чәнчү яки ыргыту коралы. *Аваз бирде Идегәй: – Таймам баскан юлымнан, Салмам сөңге кулымнан, Салмам калкан иңемнән, Яу җыярмын илемнән.* Дастан. *Каяндыр бер солдат йөгереп чыкты да мылтыклар, сөңгеләр белән коралланган бик күп җегетләр янына килеп кычкырды ---.* Г.Ибраһимов. *«Атланыгыз атларыгызга, алыгыз сөңгеләрегезне, тагыгыз чукмарларыгызны!» – дип сөрән салыр идем.* М.Әмир

2) *спорт* Җиңел атлетикада шул коралга охшаган, ераклыкка ыргытыла торган спорт әсбабы

3) *күч.* Салкында биеклектән тамып торган суның бозланып катуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән аскы башы очлы таякчык. *28 февральдә боз сөңгеләре озын икән, яз да озын булыр.* Сынамыш. *Түбәләрдән юан, озын боз сөңгеләре өзелеп төшеп, аста торган машиналарны яньчи, үткән-сүткән кешенең башын тишә.* Татарстан яшьләре

4) *күч.* Бинаның иң өске өлешенә урнаштырыла торган пирамида формасындагы очлы корылма; очлам; *русчасы:* **шпиль**

◊ **Сөңге күтәрү** Баш күтәрү, каршы чыгу. *Кенәз үзе качып киткән иде. Шуңа күрә берәү дә сөңге күтәрергә җөрьәт итмәде.* Казан утлары

**СӨҢГЕ́ АТУЧЫ** *и. к.* **сөңгече** (*1 мәгъ.*). *Сафа Гәрәй хан бөтен төрки гаскәриләре арасында иң оста сөңге атучылардан санала иде һәм, бу корал белән алышканда, беркайчан да ялгышмады.* М.Хәбибуллин

**СӨҢГЕ-КЫЛЫЧ** *җый. и.* Сөңге һәм кылыч; сугыш кораллары. *Нәрсә булса, [халык] һаман шул ук-җәясенә барып тотына, сөңге-кылычына ябыша.* Ф.Бәйрәмова

**СӨҢГЕЛӘНҮ** *ф.* Сөңге шикелле очлылану, сөңге формасын алу. *Сөңгеләнеп торган бозлар*

**Сөңгеләнә башлау** Сөңгеләнергә тотыну

**Сөңгеләнеп тору** Сөңгеләнгән хәлдә булу. *Кызның зур кара күзләре, күз тирәсендә сөңгеләнеп торган озын керфекләре Рөстәмнең күзләренә очрадылар.* Һ.Такташ

**СӨҢГЕЛЕ** *с.* 1) Сөңгесе булган; сөңге белән коралланган. *Каршысында сөңгеле дошманын күрү белән аңын җуеп егылачак ул.* Аманулла. *Сөңгеле кешеләр аның кайдалыгын чамалап өлгергәнче, ул, ян яктан ташланып, аларның берсенең сөңгесен, икенчесенең калканын бәреп төшерде.* Н.Фәттах

2) *күч.* Сөңге шикелле, чәнчә торган. *Шулай аркылыга-буйга капшана торгач, ниһаять, багорның сөңгеле башы ниндидер каты нәрсәгә барып төртелде.* Мәх. Хәсәнов. *Август чебене сөңгеле, дип юкка әйтмиләр, без белән кадагандай итте, имансыз.* Ф.Садриев

◊ **Сөңгеле Сөйләйман** Үтә дә үҗәт кеше. *Халыкча әйткәндә, сөңгеле Сөләйманнар да очраштыргалый.* З.Мансуров

**СӨҢГЕЧЕ** *и. тар.* 1) Сөңге белән коралланган сугышчы. *Кылычлы, уклы ирләрдән соң изге түгәрәккә сөңгечеләр килеп керде.* Н.Фәттах. *Истеми каханның улы Кара Чурин тәҗрибәле сугышчы, оста укчы, елгыр сөңгече була.* М.Хәбибуллин

2) *спорт к.* **сөңге ыргытучы**

**СӨҢГЕ́ ЫРГЫТУ** *и. спорт* Җиңел атлетикада сөңге ыргытудан гыйбарәт ярыш төре. *Соңыннан ук ату, сөңге ыргыту кебек сынаулар башланды.* Р.Сәгъди

**СӨҢГЕ́ ЫРГЫТУЧЫ** *и. спорт* Сөңге ыргыту белән шөгыльләнүче спортчы. *Чүкеч ыргытучылар арасында җиңүче – АКШ спортчысы Дженева Макколл, сөңге ыргытучы – Россия вәкиле Дмитрий Тарабин*

**СӨРӘКӘ** *и. диал.* Берничә метр биеклектәге озын ятьмәсе баш-башларыннан бәйләнгән агач саплардан тотып, сай җирдә елганың бар киңлегенә, төптән сөзеп, балык тота торган

җайланма; елым. *Бер яктан сөзеп чыккач карасалар, сөрәкәнең койрыгы тулы төрле зурлыкта фәкать җәен балыклары гына килеп чыкты.* Т.Нәбиуллин

**СӨРӘН** *и.* 1) *тар. хәрби* Көчле хәвефле аваз; тревога; каты кычкыру, каравыл салу. – *Тизегез!.. Тизрәк, әйдәгез!.. Әйдәгез!.. Арестантлар качтылар!.. – дип сөрән салды [хәбесханә сакчыларының берсе].* З.Бигиев

2) Оран, бәрелешкә керер алдыннан кычкыру авазы

3) *иск. этн.* Язын-җәен табигый бәла-казалардан (корылык, боз яву һ.б.) саклану, кылынган гөнаһлардан арыну, зур эшләргә керешеп, аларны уңышлы башкарып чыгу нияте белән явыз рухларны, кара көчләрне куу-сөрү йоласына бәйле мәҗүсилек чорыннан ук килә торган гадәт; бәйрәм. *Сөрән көнендә (апрель-май айларында) барлык учакларны-мичләрне сүндереп, тәләкә дигән җайланма ярдәмендә яңа ут алганнар.* Р.Әхмәтьянов

4) *иск. этн.* Авыл бәйрәмендәге атлы ярышлар, уеннар

5) *этн.* Авыл бәйрәме, гадәттә, Сабан туе алдыннан егетләр, бәйрәмчә киенеп, бизәлгән атларга атланып, бәйрәм буласын хәбәр итеп, бәйрәм бүләкләре җыеп, ярышларга өндәп, аваз салып йөрүдән гыйбарәт борынгы татар халык йоласы. *Дәр-дәр, дәрәгә, Майлы ботка казанда, Сырлы кашык базарда, Иртән торып сөрәнгә, Берсекөнгә сабанга...* Җыр. *Сагынып көткән Сабан туйлары җитте. ---- Бөтен урамнарны тутырып иңләп, кибеп җитмәгән пычракларны чатыр-чотыр чәчрәтеп, шаулап, шаярып, көлешеп: – Сөрәнгә, сөрәнгә, сөрәнгә! Сөрән беткәч, сабан-сука төрәнгә! – дип такмаклыйтакмаклый чабып йөрибез.* Ш.Маннур

6) *этн.* Гадәттә, Сабан туе үткәрү уңае белән, бәйрәм бәйгеләрендә катнашып җиңү яулаучыларга тапшыру өчен, авыл халкыннан, йорттан-йортка йөреп, гармун тартып, җырлап-биеп җыела торган бүләк, бирнә: сөлге, яулык, чигелгән эшләнмәләр, тукыма ише әйберләр. *Сөрән җыюны Фазыл һәм тагын сугыш гарасатыннан исән калган берничә егет яңа үсеп килүче һәм үзләрен зурга санаучы берничә бүлтерек белән бергә башкарды.* Н.Әхмәдиев

7) *этн.* Бүләк җыеп йөргән егетләр төркемен бәйрәм ризыгы белән сыйлау йоласы

8) Көчле яңгыраткыч система аша халыкны нинди дә булса гадәттән тыш хәл яки куркыныч вазгыять хакында кисәтү сигналы, тревога. *Сәүдә үзәгендәге бүгенге сөрәнне ишетмәүчеләр булмагандыр, мөгаен*

9) *диал.* Куркыныч кыяфәтле рух; өрәк

◊ **Сөрәнгә йөрү** Бушка сыйланып, кунак булып йөрү. **Сөрәнгә чыгу** *к.* **сөрәнгә йөрү**. **Сөрән җыены** Армия сафларына китәсе егетләрнең, таныш-белешләре, дуслары белән бергә җыелышып, бераз табын артында утырганнан соң, гармунга җырлар җырлый-җырлый, авыл урамнарын урап үтүдән гыйбарәт гадәт; армиягә озату йоласы. *Иртәгә армиягә китәсе дигән көнне җегетләр җырлап урам әйләнделәр, болай йөрүне «сөрән җыены» дип тә әйтәләр.* Р.Батулла. **Сөрән кычкыру** *к.* **сөрән салу**. **Сөрән салу** 1) Көчле ачы тавыш белән кычкыру, шул рәвешле башкаларның игътибарын җәлеп итәргә омтылу. *Әгәр борылмаса, әнисе урамга чыгып ук сөрән сала башлаячагын ул бик яхшы белә иде...* В.Нуруллин. *Очрашкан саен, Әхтәм сүзне шул якка бора, яшьләр кичке уенга җыелган җирдә Фатыйма күренсә, «әнә минем кәләш килә» дип сөрән сала.* З.Кадыйрова. – *Солтангалиев сабагын тиз онытты татарлар! – дип сөрән салды ул, залдагыларның аркалары чымырдарлык ачы тавыш белән.* Казан утлары; 2) Нәрсәгә дә булса чакырып, өндәп, нәрсәдер хәбәр итеп кычкыру, аваз салу; чыгыш ясау, фикер әйтү. *«Атланыгыз атларыгызга, алыгыз сөңгеләрегезне, тагыгыз чукмарларыгызны!» – дип сөрән салыр идем.* М.Әмир. *Хан карчыгалары сөрән салып йөргәндә, ул биек үләннәр арасында йоклап калган.* Р.Вәлиев. *Күрше вагоннан: «Безнекеләрне тукмыйлар!» – дип сөрән салдылар.* К.Кара. **Сөрән салучы** Нәрсәгә дә булса чакырып, өндәп, башкаларның игътибарын җәлеп итүче, чыгыш ясаучы, фикер әйтүче кеше. *Фәүзия Бәйрәмова кебек үз вакытында һәр иманлыкка бармак янап сөрән салучыларыбыз, кызганычка каршы, бүген бездә юк дисәң дә була.* Казан утлары. **Сөрән сугу** 1) Армия сафларына китәсе егетләр төркеме яисә кардәш гаиләләр, җыелышып, бер-берсенә кунакка йөрү йоласы. *1950 елның көзендә без армиягә китәргә җыендык. Гадәт буенча, китәсе егетләр Октябрь бәйрәме көннәрендә «сөрән сугалар», ягъни берберсенә җыелышып кунакка йөриләр.* М.Мәһдиев; 2) Эшсез, эшлексез, үзе ишеләр белән тырай тибеп йөрү. *Шулай да көн буе сөрән сугып тик йөрисе түгел әле...* Г.Бәширов. *Эштән кайткач, иптәшләр белән сөрән сугарга чыгып китәбез.* А.Расих

**СӨРӘНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Көчле хәвефле аваз белән каравыл салу, кычкыру; тревога күтәрү. *Аюның нәкъ өстенә барып чыкмас өчен, һәрвакыт кычкырып, сөрәнләп барырга кушканнар иде. Мин аларның сүзләре буенча минут саен кычкырып барам.* М.Гафури

2) *куч.* Гомумән, нәрсәгә дә булса чакырып, өндәп сөрән салу, көчле тавыш белән нык итеп кычкыру. *Бәләкәй оныгы Руслан: «Әйттем мин сезгә, картәтинең танкы дип, ә сез ышанмадыгыз, әнә бит биш йөз илле биш саны!» – дип сөрәнли.* Ә.Әминев

**Сөрәнләп алу** Бераз сөрәнләү

**Сөрәнләп йөрү** Әле, хәзерге вакытта сөрәнләү

**Сөрәнләп карау** Сөрәнләргә омтылу, тырышу. *«Аягымны авырттырдым бит!» – дип сөрәнләп тә карады.* М.Кәбиров

**Сөрәнли башлау** Сөрәнләргә керешү

**СӨРӘНЧЕ** *и. иск.* 1) Сөрәндә (*4 мәгъ.*) катнашучы

2) Сөрән (*5 мәгъ.*) йоласын башкаручы, сөрәнгә чакырып, сөрән салып йөрүче. *Сөрәнче, төргәген корал кебек тотып, тәкәббер кыяфәтен саклап чыгып китә.* А.Гадел

3) Сөрән (*6 мәгъ.*) җыюда катнашучы. *Яшел йон күлмәктән, ак шәл бөркәнеп, сөрәнчеләргә өч метр ситсы китереп бирде.* Х.Камалов

**СӨРГЕ** *и.* 1) Күз кабагына буяу тидерү өчен кулланыла торган кечкенә пумала

2) Кыллы музыка коралларында уйнар өчен, тарттырып, бер йолкым ат кылы беркетелгән агач таяктан гыйбарәт сызгыч, кәманча; *русчасы*: **смычок**

**СӨРГЕН** *и.* 1) Туган-яшәгән урыннан куып, бик еракка – читкә сөреп яшәтү җәзасы. *Авыл җитәкчесе итеп сайланган җыен әтрәк-әләм, ярлыябагай дин әһелләренә теш кайрый башлады. Контрибуция салалар, сөрген белән куркыталар.* Г.Бәширов. *Сөрген еллары, үлем белән күзгә-күз очрашулар.* Р.Миңнуллин

2) Шул җәза тәртибендә билгеләнгән яшәтү урыны. *Арыслан шул көннәрдә генә сөргеннән кайтты ---.* Г.Ибраһимов. *Әгәр дә инде бандит бирелеп килмәсә, гаиләсе ике атна эчендә сөргенгә озатыла, ә мөлкәте бандитлардан җәфа күргән крестьяннарга таратыла.* З.Зәйнуллин. *Кызыклы факт: хәтта Сахалин утравы сөрген булган вакытта да, монда мәчет һәм гыйбадәт кылу урыны булган.* Татарстан яшьләре

3) Шунда уздырылган вакыт, срок. *Мөгаен, язмыш аны тагын да олырак бәладән коткарган булгандыр – монысын инде сөргендә чагында ачык төшенде.* Ф.Яхин

4) *иск.* Кемнең дә булса терлектуарын урлап, куып алып китү. *Сөрген белән алган мал кугын белән китә, ди.* Мәкаль

**СӨРГЕНЛӘ́Ү** *ф.* Сөргенгә сөрү

**Сөргенләп бетерү** Барысын да сөргенгә сөрү

**СӨРГЕНЛЕК** *и.* Сөргенгә җибәрелгән урын һәм шунда үткәрелгән вакыт. *--- әйе, ун елдан соң безнең сөргенлек бетә.* Н.Фәттах. *Социалистик инкыйлап юлбашчысы Владимир Ленин Казанда укыган, Питрәч районында сәяси сөргенлектә булган.* Рим. Вәли

**СӨРГЕНЧЕ** *и.* Сөргенгә куылган кеше. *Гасырлар буена сөргенчеләрне, катаржаннарны күреп күнеккән җирле халык сине бар дип тә белми.* Х.Мәхмүт. *Иртән үк яңгыр яварга тотынды, төзелештәге солдатлар һәм сөргенчеләр төрлесе төрле ярыкларга кереп ышыкланган иде.* Х.Камалов

**СӨРГЕЧ** *и.* 1) *к.* **сөрге**

2) Карны сөрү, буразналау җайланмасы; кар сабаны. *Тракторлар, бурадай кар сөргечләрен тагып, ташу сулары буарга чыкканнар.* Р.Төхфәтуллин

3) Йомшак туфрак һ.б.ш. җиңел катламны сөрү җайланмасы. *Үзе рәссам, үзе көйдереп бизәүче, үзе балта остасы булган Р.Заманов әлеге сөргечләрне культиватор лапалары урынына үткен пластинкалар куеп ясый, һәм алар сиксәненче елларда район хуҗалыкларында яхшы нәтиҗә күрсәтте.* Ватаным Татарстан

**СӨРДЕРҮ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сөрү** I. *Бүренең билен сындырып, аюны аланда аунатып, боланны мөгезе белән җир сөрдереп, кайтырга дип чыктык әле.* Ф.Яруллин. *Бәрәңге бакчасын сөрдерү өчен, кимендә бер меңсум таләп ителә.* Кызыл таң

2) Сөрү, сукалау. *Тракторлар юлны сөрдереп киткәннәр.* Н.Фәттах. *Әнә Бикәнәй болынын сөрдереп харап иткәннәр.* Х.Камалов. *Мин җирне сөрдереп кайттым.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Төпле фикерләү; аңлап эш итү. *– Һай, тирәннән сөрдерә бит, килен, – диде Сабир бабай, сөенечен яшерә алмыйча.* Г.Әпсәләмов

**Сөрдерә бару** Бер-бер артлы, барысын да рәттән сөрдерү

**Сөрдерә башлау** Сөрдерергә керешү

**Сөрдерә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөрдерү

**Сөрдереп алу** Бераз сөрдерү; кыска вакыт эчендә, тиз генә сөрдерү

**Сөрдереп бетерү** Барысын да ахырына кадәр сөрдерү

**Сөрдереп йөрү** Төрле урыннарда булып, сөрдерү белән шөгыльләнү

**Сөрдереп кую** Алдан хәстәрен күреп сөрдерү, шундый хәлгә китереп әзерләү

**Сөрдереп ташлау** Кинәт, бөтенләй сөрдерү. *Шулай итеп, бүгенге көнгәчә бакчачылар үз хокуклары өчен көрәшергә мәҗбүр, алар белән йортларын сүтү, җиләк-җимеш үсентеләрен сөрдереп ташлау --- хакында килешү юк.* Кызыл таң

**Сөрдереп чыгу** Булган берсен сөрдерү, барысын да берәм-берәм сөрдерү

**СӨРДЕРҮ** II *йөкл. юн. к.* **сөрү** II. *Юк инде, бу юлы язу белән генә калмас, төрле материал җыя башласа, бөтенләй заводтан сөрдерер.* А.Алиш. *Әгәренки кыз өйгә кайтып кермәгән булса, аталы-уллы авылдан сөрдерәм мин сезне, тиомать!* М.Мәһдиев. *Хатаевич, утыз тугыз кешенең берсен дә калдырмый группировщинада гаепләп, хатка кул куйганнарның барысын да Казаннан сөрдерә, аларны Беломорканал төзергә куалар.* Р.Батулла

**СӨРЕК** *и. диал. зоол. к.* **сөйрек**

**СӨРЕЛҮ** I *ф. төш. юн. к.* **сөрү** I. *Вилдан, әрәмә сукмагыннан аерылып, сөрелмәгән җиргә керде, җир дымлы, кыш буе кар көртләрен саклаган әрәмә язгы суларны да алып калган.* А.Гыйләҗев

**СӨРЕЛҮ** II *ф. төш. юн. к.* **сөрү** II. *Сөрелүеңне туган яклардан Хөрлек итеп, җырчы, син мактан. Яшь чактан ук сиңа табигать Бүләк иткән бөек җан һәм дәрт ---.* Х.Туфан. *Кәферләр һәммәсе тәмугка сөреләләр.* Ф.Яхин

**СӨРЕМ** *и.* 1) Корымлы куе төтен; *русчасы:* **гарь**. *Тәннең тыны бетә, бөтен дөньяны төтенсыман сөрем баскан, тузан болыты йөри.* М.Мәһдиев. *Ләкин танк дөрләп яна, эчкә төтен катыш сөрем тулган, ул күзне ачыттыра.* Н.Әхмәдиев. *Цехта эссе, корым, сөрем, күлмәкләре тишкәләнгән малайлар арыган күренәләр.* Казан утлары

2) Төрле өслекләргә утыра торган корым; *русчасы:* **копоть**. *Кичләрен чаршауларга, пәрдәләргә, сөлге-тастымалларга кара сөрем утыра.* Г.Бәширов. *Пыялаларга тузан, сөрем кунган.* Н.Хәсәнов

3) *күч.* Үткәннән килә торган начар гадәт, тискәре сыйфат; зарарлы караш. *«Коммунист Харисов солдатларның аңын дин сөреме белән агулый», – дигән гайбәт таралса, --- андагы офицерлар даны-намусына утлы шелтә яңгыр урынына ява башларга мөмкин.* С.Поварисов. *Шушы минутта Гайфетдин абзый гарәп имласы белән язуның искелек сөреме, диндарлык билгесе икәнлеген --- тагын бер кат исенә*

*төшереп алды.* Ф.Яхин. *Хәмер сөреме зиһененә йөгергәч, Кудрявцев, урыныннан кубып, полковник Сергеевны кочып алды.* В.Имамов

4) *күч.* Караңгылык, наданлык; грамотасызлык. *Кайбер кешеләр үз акылларына һәм зиһеннәренә таянып галим булырлар, нининдер серләрне вә хикмәтләрне ачарлар, сан һәм дәрәҗә алырлар, әмма барыбер наданлык сөременнән тәмам котылып бетә алмаслар ---.* Ф.Яхин. *Бер карасаң, кайчандыр элеккегедәге тоташ бер кара сөремнән халык күпмедер аңга-белемгә чыкты.* Казан утлары

5) Ис; *русчасы:* **угар**. – *Сөрем исертә икән, – диде ул Андрей Войковка, авызын зур итеп ачып иснәп тә куйды.* Г.Әпсәләмов

6) *күч.* Авырлык, кыенлык һ.б.ш. нәрсә тәэсире, шуның билгесе, чагылышы. *Менә ул, анасының беләкләрендә яткан килеш, моңарчы бер генә кайгы сөреме дә керләндермәгән, бер генә ачы күз яше дә төсен уңдырмаган, чык тамчысыдай ачык-саф күзләре белән анасына караган хәлдә имеп ятадыр.* Г.Бәширов. *Нишлисең, яшьлек бит, баш түбәсеннән хәсрәт сөреме бөркелеп торса да, мин шул чибәрләргә кызыксынып карамыйча булдыра алмыйм.* Ә.Еники. *Кайбер балаларның күзендә ятимлек сөреме була.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Шаукым, кәсафәт, начар йогынты. *Мәхәббәт бакчасында, кызыл гөлләр эчендә күбәләктәй уйнаган ялкынлы яшьлегемне гайбәт сөреме белән агуларга уйлыйлармы?* Г.Ибраһимов. *Өчме-дүртме ай читтә яшәп кайткан бабабызның артыннан кара сөрем булып гайбәт килеп төшкән: ул андагы авыл советы секретаре белән бәйләнгән, имеш.* М.Маликова

8) *күч.* Күңелне басып, чолгап алган, аңны томалаган уй-кичерешләр, хисләр. *Атна-ун көннәр узгач, чын мәхәббәт сөременнән бераз айнып, алар чыгыш ясаган мәдәният сарае төбенә килсә, циркләры бу тарафлардан инде күптән киткән.* А.Хәсәнов. *Мин аларны моң сөременә батып озатып калдым.* Р.Гариф

◊ **Сөреме коелу** *к.* **сөмсере коелу**. *Мин чыгыйм әле, аның бүген болай да сөремнәре коелып тора...* Ә.Еники. **Сөрем кабу** Ис (*4 мәгъ.*) тию

**СӨРЕМЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **сөремләнү** I (*5 мәгъ.*). *Кыстатып-кыстатып эчкән ике чынаяк аракы аның башын яхшы ук сөремләндергән иде.* Ш.Камал

**СӨРЕМЛӘНҮ** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өсте сөрем белән каплану. *Сөремләнгән куыгын сөртештергәндәй итте.* М.Хәсәнов. *Сөремләнеп, пуля, снаряд, мина һәм бомба кыйпылчыклары тиеп теткәләнеп беткән, түбәсез, түшәмсез ярымҗимерек диварлар.* Р.Мостафин. *Акшарлары сөремләнеп карала төшкән ипи миче.* Н.Хәсәнов

2) Янганда сөрем чыгару; сөремләү. *Каһәр төшкән нәрсә [лампа], нигәдер сөремләнмәкче була, ара-тирә, сүнәргә теләгәндәй, өзек-өзек талпынып куя.* А.Шамов. *Тагын бер киңәш: әгәр дә ит пешкән вакытта күмер өстенә бернечә уч эре тоз сипсәгез, учак ялкынланып китмәс, кызган күмергә тамган май сөремләнмәс.* Кәеф ничек?

3) Эче сөрем белән тулу (бүлмә тур.)

4) Сөрем белән катнашу. *Киң Идел өстен аккош сыман ак пароход белән ярып барганда, ерак булып, офык читендә зәңгәр сөремләнеп, Казан шәһәре күренә.* А.Алиш

5) *к.* **сөремләү** (*3 мәгъ.*). *Сыра чөмереп, аңы сөремләнгән*

6) *күч.* Бозылу, кирегә китү, таркалу. *Арабызда мөнәсәбәтләр бозылу-сөремләнү ихтималы туды. Ләкин әбекәебезнең акыллылыгы, беркатлы, мәрхәмәтле карчык булуы безне бу кыенлыктан коткарды.* Л.-Х.Таналин

7) *күч.* Күренү, сизелү; шәйләнү. *Ләкин Тәбрикнең йөзендә әллә нинди – нәфрәткә охшаш ачу сөремләнә иде...* Ә.Баян

**Сөремләнә бару** Торган саен ныграк сөремләнү

**Сөремләнә башлау** Сөремләнү билгеләре күренү

**Сөремләнә төшү** Бераз сөремләнү

**Сөремләнеп бетү** Тәмам сөремләнү

**Сөремләнеп калу** Билгеле бер сәбәптән соң сөремләнгән хәлгә килү

**Сөремләнеп килү** Акрын гына сөремләнү

**Сөремләнеп китү** Көтмәгәндә сөремләнү

**Сөремләнеп тору** Әле, хәзер сөремләнү

**СӨРЕМЛӘНҮ** II *и.* Сөрем белән каплану процессы. *Мич өстендә сөремләнүдән чем кара төскә кергән чәйнек тора.* Мәх. Хәсәнов

**СӨРЕМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Янганда, корымлы куе төтен, сөрем чыгару. *Ни сәбәпле ун яшьлек малайны, укуыннан аерып, кеп-кечкенә бер авылның сукыр лампа шикелле сөремләп кенә утырган кадим мәдрәсәсенә илтергә?* Г.Бәширов

2) Сөрем чыгару, сөрем белән катнаштыру, сөремле итү. *Машина газларының урам һавасын сөремләп агулавы*

3) *күч.* Аңны томалау, зиһенне чуалту; исертү

**Сөремләп алу** Беркадәр вакыт, бераз сөремләү

**Сөремләп бетерү** Тәмам сөремләнгән хәлгә китерү

**Сөремләп тору** Даими рәвештә сөремләү

**Сөремләп утыру** Әле, хәзер, туктаусыз, акрын гына сөремләү

**Сөремли башлау** Сөремләү билгеләре күренү

**СӨРЕМЛЕ** *с.* 1) Сөрем чыгарып яна торган. *Йөрәк итенә кереп кадалган кадак дип әйтимме – ул да түгел, якты кояшны каплап торган черек багана диммe – ул да түгел, әллә яшь чәчәкләр өстенә агулы корым таратып яткан зәһәр сөремле морҗа дип әйтимме – ул да түгел ...* Г.Ибраһимов. *Вентиляция каналларының дөрес эшләмәве бина эченә сөремле газ таралуга китерә*

2) Сөремләнгән, сөрем таралган; сөрем каплаган. *Шул сөремле томан эченнән колагына тимер чыңы ишетелде.* Г.Әпсәләмов. *Җылы, сөремле кич. Кайдадыр яңгыр ява булса кирәк, йомшак кына гөлдерәү ишетелеп ала.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Берникадәр карлыккан, басынкы. *Хәрәкәтчән, егәрле, тормышчан ханым өчен артык басынкы, сөремле, бастырыклы тавыш белән өстәп куйды: «Икебезне дә язмыш җитәрлек сынады».* Т.Галиуллин

4) *күч.* Тискәре, авыр (гомуми вазгыять тур.)

**СӨРЕНТЕ** *и.* **1.** Сөрелә, эшкәртелә торган җир; сөрү җире. *Фәнни күзлектән караганда, республикада барлык сөрентеләрнең 70 проценты чамасы таулы урыннарда урнашкан.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Сөрелә торган, сөрү өчен билгеләнгән. *Галимнәр билгеләвенчә, республикада мал азыгына тәгаенләнгән сөренте җирләрнең продуктлылыгы елдан-ел кими.* Кызыл таң

**СӨРЕШ** *и.* Барыш; агым, процесс. *Сүз сөреше ул теләгән якка таба кереп киткәнгә эченнән генә куанып, Вәлиулла сорау бирергә ашыкты: – Ә нигә беткән, таркалган соң авыл?* Р.Низами. *Ат акрын гына атлый, фикер сөреше ат адымына тәңгәл.* М.Хәбибуллин

**СӨРКӘ** *и. диал.* 1) *зоол.* Тиеннәр семьялыгыннан тирән өндә яшәүче, кышын йокыга тала торган кимерүче җәнлек; байбак, суыр; *русчасы:* **сурок**. *Шифаханә хезмәткәрләре һәм ял итүчеләр оештырган әлеге бәйрәм сөркәне кышкы йокыга озату уңаеннан уздырылды.* Татарстан яшьләре. *Шәһәрдән Шөгер ягына таба барганда, безне сөркәләр утырып озатып кала.* Заман сулышы

2) Шул җәнлекнең тиресе. *Сөркә сатучылар*

**СӨРЛЕГҮ** I *ф.* 1) Абыну. *Нургали, сөрлегеп, абзар кырыендагы сыер тизәгенә авызы белән барып төште.* М.Мәһдиев

2) Үсемлекләр җил, яңгыр һ.б.ш.лар тәэсирендә берәр якка авышу, аву, яту. *Гөлләр җиргә сөрлегә Чәчәкләре көчлегә. Мин дә шулай бөгелеп төштем Шушы гөлләр төслегә.* Х.Туфан. *Җил уңаена бодай әзрәк сөрлеккән сөрлегүен дә, күтәрелер әле.* Г.Әпсәләмов

3) Сыгылып төшү. *Шофёр егет, авырткан җиренә кагылгандай, йөзен чыткан, гәүдәсе белән бөрешеп, рульгә сөрлеккән иде.* Р.Вәлиев

4) Ишле төркем кинәт бер якка кузгалу, авышу. *Абзардагы сарыклар куркышып бер читкә сөрлектеләр.* Ф.Хөсни. *Нинди эш башкаруларына карамастан, кешеләр, бер карусыз аларның әмеренә буйсынып, читкә сөрлегеп калалар.* Ф.Абдуллин

5) Туктаганчы берникадәр шуып бару. *Фаил тормозга басуга, машина сөрлегеп туктады.* Р.Вәлиев

6) *күч.* Уңышсызлыкка очрау, бәхетсезлеккә тару; ялгышлык эшләү. *Түбәнге баскычта ук сөрлеккән талипталибәнең якты киләчәгенә, ил гыйлеменә өлеш кертүенә кем ышансын да, --- күзле бүкәнне, шыр наданны тыңлап, заяга вакытын уздырып утырсын, ди.* Т.Галиуллин. *Я, Салихҗан дус, эшләр ничек бара? Ноталар урманында адашып, сөрлегеп калмадыңмы?* Р.Низамиев

**Сөрлегә башлау** Сөрлегергә тотыну; сөрлегү билгеләре күренү

**Сөрлегә язу** Чак кына сөрлекмәү

**Сөрлегеп алу** Бер ара яки бер тапкыр сөрлегү. *Ярты сәгатьләп тартышкач, үгез котыртучының хәле кими башлады бит, бер-ике мәртәбә сөрлегеп тә алды.* Н.Әхмәдиев

**Сөрлегеп калу** Ниндидер тәэсирдән, вакыйгадан соң сөрлеккән хәлгә килү. *Исеме мәгълүм байтак кына әдипләрнең иҗаты тукталып, сөрлегеп калды.* М.Вәли-Барҗылы

**Сөрлегеп китү** Кинәт кенә сөрлегү. *Сары баш сөрлегеп китте, ләкин егылмады ---.* Р.Вәлиев. *[Вәлиулла] бер-ике тапкыр сөрлегеп китеп, чак каплланмады.* Ф.Яхин. *Әмма ул кинәт кенә сөрлегеп китте дә, күтәреп барган бөтен нәрсәсе асфальт юлга чәчелде.* Сөембикә

**Сөрлегеп кую** Кинәт бер мәртәбә сөрлегү

**СӨРЛЕГҮ** II *и.* Сөрлегү гамәле, шул процесс. *Ләкин дөя сөрлегүгә карап, кәрван туктамаган шикелле, клиника тормышы да, Яңгура килмәүгә карап, үзенең авыр, газаплы агышыннан туктамады.* Г.Әпсәләмов. *Клуб баскычыннан йөгереп төшкәндә үк, аның үкчәле туфлиләре сөрлегүдән төшеп калды.* М.Мәһдиев

**СӨРМӘ** *и.* 1) *хим.* Көмешсыман аксыл, уалучан металл, химик элемент; *русчасы:* **сурьма**

2) Бизәнү максаты белән чәч, каш, керфек һ.б.ны каралта торган буяу. *Әмма, күп очракта, кершәне туры килсә, сөрмәсе дөрес тартылмый яисә чәчен оештыра алмыйча аптырап бетә [Айгөл Җәүдәтовна].* Ф.Яхин

◊ **Сөрмә тарту** Каш, күз, керфекләрне сөрмә белән (*2 мәгъ.*) буяу. *Ә хикмәтле сөрмә тартмасының сере шунда: ул тартмадан сөрмә тарткан кеше яшерен хәзинәләрне күрәчәк.* Әкият. *Чамадан тыш кыланмасалар, ирен кызартулары, каш-керфекләренә сөрмә тартулары килешеп тора тагын ул чукынчыкларның.* Н.Әхмәдиев

**СӨРМӘЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **сөрмәләү**. *Аның күз төпләре күмер белән сөрмәләнгән.* Һ.Такташ. *Аның әле чәчләре дә кибеп өлгермәгән, ике бите уттай яна, күз төпләре сөрмәләнеп уелган, ә тыгыз, сылу гәүдәсеннән дымлы хуш ис (әллә теге каен себеркесенең мәтрүшкә исе) аңкып тора.* Ә.Еники

**Сөрмәләнеп тору** Сөрмәләнгән хәлдә яки сөрмәләнгән кебек булу. *Искәндәр урыныннан торып, терраса коймасы өстенә бер боты белән генә утырып, киң аллея аркылы инешнең ялтырап күренүен, аның артындагы киң, кырыйсыз киң яшел болынның сөрмәләнеп торуын, --- туя алмыйча карыйкарый, тирән уйга чумды.* К.Тинчурин

**СӨРМӘЛӘҮ** *ф.* Сөрмә тарту, сөрмәгә буяу. *Ирем икенче хатын алмасын дип, сөрмәлидер кашларын [Байбикә].* Ш.Мөхәммәдев

**Сөрмәләп алу** Бераз, тиз генә яки бер тапкыр сөрмәләү

**Сөрмәләп бетерү** Бөтенләй, бар нәрсәсен дә сөрмәләү

**Сөрмәләп җибәрү** Бераз сөрмәләү; башка бер эшкә, гамәлгә өстәп сөрмәләү

**Сөрмәләп тору** Хәзер, шушы моментта сөрмәләү; даими, бер-бер артлы сөрмәләү. *Күзләрен уратып алган куе керфекләре, буямыйча да кашларына кадәр җитеп, күзләрен матур гына сөрмәләп торалар, дип уйлап ялгышкан икән бит [Рәхилә]!* Л.Ибраһимова

**Сөрмәләп чыгу** Барысын да рәттән ахырына кадәр сөрмәләү

**Сөрмәли башлау** Сөрмәләргә керешү

**СӨРМӘЛЕ** *с.* 1) Составында сөрмә (*1 мәгъ.*) булган, сөрмә белән катыш. *Сөрмәле көмеш*

2) Сөрмә (*2 мәгъ.*) тарткан, сөрмәгә буялган (каш, күз һ.б. тур.). *Егетләр кызлар тирәсендә буталып йөри торгач, бер шәльяулык читеннән, очкын чәчрәгәндәй, сөрмәле күз сирпелеп китте.* Г.Бәширов. *Аннан тыйнак нәфислек, хисләр тирәнлеге бөркелеп тора, яшь кызларныкы кебек җиңел сөякле зифа гәүдәсе, янып торган бит алмалары, сөрмәле зәңгәр күзләре теләсә нинди егетне дә гашыйк итәрлек.* М.Маликова. *Пәрәнҗә япкан бу хатынның йөзе тулысынча күренмәсә дә, сызылып киткән кара кашлары астыннан каймаланып торган сөрмәле керфекләре аша караңгы, чем кара күзләре үзгә бер мөлаемлык белән иренә текәлгән.* Сөембикә

3) Табигый рәвештә сөрмәләнеп торганга охшаган, күз төпләренә сөрмә тарткан кебек. *Рушания кыяр-кыймас кына каршысына килеп баскан егеткә күтәрелеп карады, каршысында торган егетнең сөрмәле зәңгәр күзләренең матурлыгы әсир итте ---.* З.Кадыйрова

**СӨРСЕК** *и.* Сасы, сөрсегән ис. *Сөрсеге килә*

**СӨРСҮ** *ф.* 1) Бозылып, начар, сасы ис чыгара башлау. *Песинең иткә бue җитмәгәч, сөрсегән, дип әйтә, ди.* Мәкаль. *Нургали абый, нигә яңа базны ачтырмыйсың, бүген таңда бозауларга торган сыерга сөрсегән силос биреп булмый бит.* Ә.Еники. *Сөрсегән печәнлегегездә мине изеп, бала әвәләп бирдең дә, хәзер кирәгем беттеме?* Ф.Яруллин

2) Начарлану, бозылу; исләнү (су, һава тур.). *Ул балыклар елдан-ел кими бара. Чөнки сөрсегән, тынчу суда ничек яшәмәк кирәк?* Т.Нурмөхәммәтов. *Безнең тормыш сөрсегән күлгә охшап бара сыман.* Ф.Яруллин. *Бүлмәңнең сөрсегән һавасын сулыйсым һич тә килми.* М.Хуҗин

3) *күч.* Озак вакыт берни үзгәртмичә, гадәтләнгәнчә, искечә яшәү, эшләү, шул рәвешле тормыштан артта калу. *Шуңа күрә, берни эшләмичә тик ятып сөрсүгә караганда, мәгънәсез эш тә яхшырак.* Г.Әпсәләмов

4) *күч.* Замана таләпләренә туры килмәү, яңалыгын җую, нык искерү. *Син бигрәк иске – коммунистлар хакимияте заманыннан калган, сөрсегән, яманаты чыккан терминнар белән эш итәсең: көрәш ачарга, юкка чыгарырга!* Т.Галиуллин. *Сөрсегән тәртипләр*

**Сөрсеп бару** Торган саен ныграк сөрсү. *Өй белән редакцияләр арасында йөреп, сөрсеп барам бугай инде.* Л.Ихсанова

**Сөрсеп бетү** Тәмам, бик нык сөрсү. *Авылда ятып, сөрсеп беткән, диегез.* Т.Миңнуллин. *Әйе, хәзер аңлавымча, тора-бара, мин күп мәсьәләләрдә бозылып, сөрсеп беткәнмен, гарипләнгәнмен ---.* А.Тимергалин. *Синең сөрсеп беткән шәһәрең түгел инде ул.* Р.Вәлиев

**Сөрсеп яту** Күпмедер вакыт дәвамында, озак вакыт сөрсү. *Безнең кебек малайларга монда сөрсеп яту килешми.* Н.Гыйматдинова. *Миннән башка эт тә килми бит синең яныңа. Ярар, китәм. Миңа нәрсә, ят шунда берүзең сөрсеп!* В.Нуруллин. *Һашимовны да алып чыгыйм әле, мәйтәм, сөрсеп ятмасын.* Р.Зәйдулла

**Сөрси башлау** Сөрсү билгеләре сизелү

**СӨРТЕНГЕЧ** *и.* **1.** Сөртенү өчен кулланыла торган чүпрәк; сөлге

**2.** *с. мәгъ.* Сөртенү өчен куланыла торган, шуның өчен билгеләнгән. *Сөртенгеч яулык*

**СӨРТЕНҮ** I *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **сөртү** I (*3 мәгъ.*). *Ямгырчы би, Койтым бикәнең үзе генә өйдә чагын белешеп, сагалап торды да, яхшырак киенеп, чәченә, сакал-мыегына исле майлар сөртенеп, ялгыз өйгә юнәлде.* Н.Фәттах. *Егет очрашуга әзерләнгән: чәчләрен тараган, аңкытып, хушбуй сөртенгән иде.* Н.Гыйматдинова

2) Юынгач яки тирләгәннән соң тәннең юешен сөртү. *Яшел чирәмдә генә комганнан кулларны югалап, рәшәткә башына элгән озын сөлге белән сөртенеп, өс-башның да тузанын бераз сыпыргалаштырып, Гобәйдулла артыннан өйнең түр як башына уздык.* Ә.Еники. *Сөлгене алып, аннан-моннан гына сөртенеп, өстемә халат элдем.* М.Кәбиров

**Сөртенә башлау** Сөртенергә керешү

**Сөртенеп алу** Тиз генә, җитез хәрәкәтләр ясап сөртенү. *Битемне югандай итәм дә сөлгегә сөртенеп алам.* Т.Нурмөхәммәтов

**Сөртенеп кую** Алдан хәстәрен күреп сөртенү

**Сөртенеп ташлау** Кинәт, җитез хәрәкәтләр ясап сөртенү

**Сөртенеп тору** Әледән-әле яки хәзер сөртенү

**СӨРТЕНҮ** II *ф.* 1) Абыну. *Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем.* Г.Камал. *[Шакирҗан] кинәт, сикереп чыгам дип, сөртенеп, пычрактан канлы башы гына күренеп торган бер мәет өстенә егылды.* К.Тинчурин. *Хәйбулла алдан баручы финны да чак-чак кына абайлый башлады. Атлаган саен диярлек сөртенде.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Эштә-тормышта ялгышлык эшләү, хаталану; уңышсызлыкка очрау, бәхетсезлеккә тару. *Ләкин, туташ, сөртенгән нәрсәгез – мәхәббәт ул.* М.Фәйзи. *Рәйсә яшьләй сөртенеп куймагае, дип куркам.* М.Хуҗин

**Сөртенә язу** Чак кына сөртенми калу

**Сөртенеп китү** Кинәт сөртенү. *Фабарисов, ашыгып, аның каршына килде, тигез урында сөртенеп китте.* Ф.Бәйрәмова

**Сөртенеп кую** Бер мәртәбә сөртенү

**СӨРТКЕЧ** *и.* Сөртеп I (*1, 2 мәгъ.*) чистарта торган әйбер. *Ул аягын баскыч төбендәге резина сөрткечкә ышкыды.* М.Мәһдиев

**СӨРТҮ** I *ф.* 1) Кул белән, чүпрәк яки башка махсус сөрткеч кулланып, берәр өслектән нәрсәне дә булса бетерү, алу, китәрү. *Гайшә ханым исә, үксүдән бераз туктап, күзеннән яшьләрен сөртте ---.* З.Бигиев. *Яулык чыгарып, маңгай тирләремне сөртергә тотындым.* Г.Кутуй

2) Чистарту максаты белән юештән, пычрактан, чүптән арындыру. *Кичә, кипкән йонга аягын сөрткән өчен, [киң җилкәле, кара мыеклы кеше] Фәттахның яңагына шундый кундырды, пишкадәм дип тормады.* К.Тинчурин. *Ул [Альберт] күзлеген салды да, кәнәфи ертыгыннан чыгып торган паролон кисәге алып, пыялаларын сөртте.* А.Тимергалин

3) Сылау, ягу, сылап йоктыру; уу, ышку. – *Мазь булыр. Йоклар алдыннан*

*сөртерсең, – дип кенә [авыруны] карауларны туктаттым.* Г.Кутуй

4) Сибү; пошкырту. *[Кызлар] кечкенә көзге тирәсенә өелешеп, чәчләрен төзәтәләр, түшләренә хушбуй сөртәләр, кершән ягынып, бит очларына иннекләр сөртеп, күзләренә сөрмә тартып купшыланалар.* Г.Бәширов

5) *күч. сөйл.* Урлау. *Берәр яшь шагыйрьнекен сөртмәгән булсаң. Бик ышанып та җитмим. Син менә безнең алда чыгар [шигырьне].* Г.Мөхәммәтшин

**Сөртә бару** Барысын да рәттән сөртү

**Сөртә башлау** Сөртергә керешү. *[Җылкычы ата] «Булдым, биргәнеңә шөкер», – дип, майлы кулларын итек кунычларына сөртә башлады.* Г.Ибраһимов

**Сөртә бирү** Бернәрсәгә карамастан сөртү

**Сөртә тору** Берәр хәлгә кадәр сөртү

**Сөртеп алу** Тиз генә, җитез хәрәкәтләр ясап сөртү. *Әхәт абый, кулындагы балтасын бүкәнгә чабып, маңгайларын сөртеп алды.* Г.Бәширов. *– Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, – диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.* Ә.Еники. *Егет --- эшнең нидә икәнен аңлады бугай, итәк чабуын төшерде дә бармак очы белән генә Фатыйманың күз яшен сөртеп алды.* З.Кадыйрова

**Сөртеп бетерү** Тәмам, ахыргача, берсен дә калдырмыйча сөртү. *Мин аның рәсемнәрен бозып, буяп, сөртеп бетердем.* З.Хәким

**Сөртеп йөрү** Даими, һәрвакыт сөртү; әле, хәзер сөртү белән шөгыльләнү. *Чит-ят артын сөртеп йөргән ялчыдан юньле кеше чыкмас.* В.Имамов

**Сөртеп җибәрү** Бераз сөртү; башка бер эшнең дәвамы итеп сөртү. *Тагын китереп сөлге төртте: – Битне сөртеп җибәр менә!* Г.Афзал

**Сөртеп кую** Бер мәртәбә сөртү; алдан сөртү. *Шуннан [дога кылганнан соң яхшы төш күрүче] куллары белән битен сөртеп куярга тиешле.* Ф.Яхин. *--- Юлай җиң очы белән күз яшен сөртеп куйды.* З.Кадыйрова

**Сөртеп тору** Әле, хәзерге вакытта яки даими сөртү

**Сөртеп ташлау** Тиз арада, аннанмоннан сөртү

**Сөртеп чыгу** Барысын да тоташтан сөртү. *Аннары ул, йөрәк сагышларын басарга тырышып, мопедын чистартырга тотынды: канатларны, кыршауларны, хәтта тимерчыбык кигиләрне дә бөрәмтекләп сөртеп чыкты.* А.Тимергалин

**СӨРТҮ** II *и.* Сөртү I (*1–3 мәгъ.*) эше, процессы. *Ә инде иртән торуга юеш сөлге белән тәнеңне сөртүгә калса, гафу итәсез.* М.Мәһдиев. *Кисекбашның йөзеннән Галинең үбүе, күз яшьләрен сөртүе – болар аны юатуы һәм Галинең аңа соклануы да.* Ф.Яхин

**СӨРҮ** I *ф.* **1.** 1) Туфракны сабан белән ерып йомшарту. *[Гөлнур:] Чулак Шәрәфи, уртактан сөреп, уҗымны чәчәргә булды да, Сәрвәр терелми бит. [Җиһанша:] Орлык та уртакмы?* К.Тинчурин. *Дүрт йөз туксан дүрт гектар җирнең өч йөз җитмеш гектарын сөреп чәчәсе бар.* В.Нуруллин

2) *күч.* Юл уңаенда торган нәрсәләрне таптап, ватып-җимереп, җир өстен актарып, ертып, ермачлап бетерү (дуңгыз һ.б.ш. хайваннар тур.). *Икенче көнне үк зиратка бозаулар, дуңгызлар кереп, каберләрне таптап, сөреп чыккан.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Аяк астындагы пычракны, карны һ.б.ш.ны изеп, ерып бару. *Әле дә исемдә, яңа гына каты сугыш булып үткән, хәрабә хәленә килгән урам буйлап пычрак сөрә-сөрә барам.* А.Шамов

4) *күч.* Сүтү, җимерү, юк итү. *Ул бинаны сез туганчы ук сөреп ташладылар.* А.Азимов

5) *күч.* Җентекләп өйрәнү, тикшерү. *Язучының иҗатын сөреп чыгу*

**2.** *рәв. мәгъ.* Күпләп. *Әйтерсең мәктәп баласы каникулда сөреп акча эшли.* Татарстан яшьләре

◊ **Сөрмәгән җир өстендә тумаган куян баласы** Булмаганны булган итеп, ялган сөйләү турында

**Сөрә бару** Бер-бер артлы, барысын да рәттән сөрү

**Сөрә башлау** Сөрергә керешү

**Сөреп бетерү** Барысын да тоташтан ахырына кадәр сөрү. *Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр – барысы да күмелеп калды шунда...* Ә.Еники. *Надыйров, бик нык тарткалашып кына, чишмә болынын сөреп бетерергә бирмәде.* Х.Камалов

**Сөреп йөрү** Төрле урыннарда сөрү белән шөгыльләнү. *Бу кечкенә кеше аты, сукасы белән җир сөреп йөри икән.* Миф. *Кыр станында куна-төнә сабан сөреп йөргәндә, төшке ашка утырсак, без – яшь-җилбәзәкләр – япон сугышында катнашкан Асылгәрәй карттан Порт-Артур турында сөйләтә идек.* М.Юныс

**Сөреп карау** Сынау максаты белән сөрү. *Сабан ташлап калдыру – җиңел эш ул, син менә ике сабан белән сөреп кара, алай бик оста булсаң.* Н.Фәттах

**Сөреп кую** Сөрелгән хәлгә китереп әзерләү. *Мәсьәләгә төшенгәч, ул беркадәр йомшый төште: – Сөреп куюың яхшы булган, – диде ул.* Н.Фәттах

**Сөреп ташлау** Тиз арада сөрү; барысын да сөрү. *Ачы әрем исе, камыл исе, сөреп ташланган туфрак исе Иргалинең җанын айкап алгандай итте.* М.Хәсәнов

**Сөреп чыгу** Булган берсен сөрү, барысын да сөрү. *Дөресен әйтергә кирәк, Ишмөхәммәтов Тукай иҗатын шактый тирән сөреп чыккан.* Ә.Еники. *Хәер, бу вакытка Америка авиациясе шәһәрне бомбалар белән сөреп чыккан була.* А.Тимергалин

**СӨРҮ** II *ф.* 1) Ачуланып, куу, куып җибәрү; бөтенләйгә китәргә мәҗбүр итү. *Менә әле син, Совет чыккач, бер кыш булса да укып калдың. Кызыллар илдән акларны сөреп чыгаргач, тагын укырсың...* Г.Гобәй. *Партиядән сөргәннәр, ырр-ырр!* Т.Гыйззәт

2) Җәза тәртибендә сөргенгә җибәрү. *Ахыр чиктә, бөтен җирдә мәчетләрне ябып, муллаларын сөреп яки үтереп бетерделәр.* Ә.Еники. *Башта, «авыл бае» тамгасы тагып, Мөгълифәнең әтисен сөргенгә сөргәннәр.* К.Тимбикова

3) Көчләп хәрәкәт иттерү; куалау. *Сугыш елларының кырыс тормышы географларның семьясын мәктәптән мәктәпкә сөреп йөрткән, боларның бала-чага да, кием-салым да юк, үзләре*

*белән бер-ике бәйләм китаплары гына бар.* М.Мәһдиев. *Ул ауны салган иде, Хак Тәгалә фәрештәләргә әмер итте дә, алар ау тулганчы балыкларны сөреп керттеләр.* Х.Мәхмүтов

4) Куу, тарату, бетерү. *Әхлак, вөҗдан, Инсафларны Сөреп чыгардык истән дә; Бозылдык шулкадәр начар: Уздырдык без Иблистән дә.* Г.Тукай

**Сөрә бару** Бер-бер артлы, барысын да рәттән сөрү

**Сөрә башлау** Сөрергә тотыну

**Сөреп бетерү** Тәмам, барысын да, соңгысына кадәр сөрү

**СӨРҮ** III *ф.* 1) *Көн, гомер, тормыш* кебек сүзләр белән: яшәү, кичерү, алып бару, үткәрү; дәвам итү. *Менә шулай ике ел инде хатынсыз торамын. Мәрхүмә белән унтугыз ел гомер сөрдем.* З.Бигиев. *Золмәт һаман көн сөрәлмәс!* С.Рәмиев. *[Фронтовик Шәүкәт] хәзер төп йортта ялгызы тормыш сөрә.* Якты юл

2) Күрү, тату; кору (кәеф-сафа, рәхәтлек һ.б.ш. тур.). *Байлар бик күп йөрделәр. Төрле рәхәт сөрделәр.* Г.Камал

3) Башкару, эш йөртү, эш итү; гамәлгә ашыру. *Әле монда һаман Садыйк бай хуҗалык сөрәмени?* Ш.Камал. *Патшалык сөрү*

**Сөреп яту** Озак вакытлардан бирле сөрү, үткәрү. *Шунысы гыйбрәтле: бу йортта озак еллар безнең буын вәкиле Искәндәр Гомәр углы Әмирхан гомер сөреп ятты.* Р.Әмирхан

**СӨРҮ** IV *ф. иск.* Якын китерү; тидерү. *Вә ул хәлвәте хөҗрәдә бер кыз, бер егет калды, һаман сәгать хәлвәфрүш аяк үзрә торып, кызны югары утыртты вә, аягына йөзен сөреп, гозерләр теләде.* К.Насыйри

**СӨРҮЛЕ** *с.* Сөрелә торган; сөрелгән. *Елга-инеш буйларындагы ташу белән ашланган җирләрдә карбызкавын, татлы виноград үстергәннәр, сөрүле басуларда иген иккәннәр ---.* М.Хәбибуллин

**СӨРҮЛЕК** *с.* **1.** Сөрүгә яраклы; сөрелә торган. *Камалетдинов колхозның сөрүлек җирләр планын сорап алды.* Т.Гарипова

**2.** *и. мәгъ.* Сөрүгә яраклы яки сөрелә торган җир. *Республика буенча сөрүлекләр бер колхозга уртача дүрт мең ярым гектар чамасы туры килә.* Казан утлары

**СӨРХӘНТӘЙ** *и.* **1.** Эш сөймәс, кәеф-сафа корып йөрүче, ялкау кеше. *Кемгә карап шундый сөрхәнтәй булдыгыз сез, ә?* Ф.Яруллин. *Ләкин без авыл кавеменнән шул, шәһәр сөрхәнтәйләре түгел.* Н.Әхмәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Кулыннан эш килмәгән, кәеф-сафа корып йөрергә яраткан, ялкау. *Минем эшлексез, паразит, сөрхәнтәй кешеләрне җенем сөйми.* Г.Бәширов

**СӨТ** *и.* 1) Хатын-кызның, имезүче ана хайваннарның махсус бизләреннән бүленеп чыга торган һәм имезү чорында яшь баланы яки яңа туган хайванны туйдыра торган ак сыекча. *Ил китәрдә ни калыр? Ил китәрдә йорт калыр, Йорт китәрдә сөт калыр, Ак күкрәктән сөт имгән Сүзе татлы тел калыр.* Дастан. --- *[сыерлар] башларын югарырак күтәреп, эре атлап, өйдәге бозауларын имезергә, артык сөтләрен саудырырга ашыгып кайтмыйлар.* А.Таһиров

2) Сыер, кәҗә, ат һ.б.ш. кайбер хайваннардан савып алып, шул килеш яки эшкәртеп, азык сыйфатында кулланыла торган сыекча. *Бер биядә ике имчәк: Бере кипсә, беренең сөте юк ---.* Дастан. – *Карынымда каты таш бар кебек, шул җанлы әйбердәй кузгалып йөргән кебек... – дип газап чигә [Сатирә]. Сөт сорый, ләкин сыер былтыр ук сатылган иде инде...* Г.Ибраһимов. --- *иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде [әби], тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты.* Ә.Еники

3) Кайбер үсемлекләрдә була торган, гадәттә, ябышкак ак яки аксыл сут. *[Кәҗә] сөтлегән үсемлеген дә бик яратып ашый, күпме генә ашаса да, бу вакытта аның сөте кешеләр һәм башка организмнар өчен агулы булса да, кәҗә агуланмый.* Ф.Закиров. *Кокос сөте*

4) Кайбер матдәләрнең ак яки аксыл эремәсе. *Завод бик иске шул, купец Любимовлар заманында ук салынган. Известь сөте куып торучы поршеньлы насослар тузып беткән.* Г.Ахунов. *Цемент сөте*

◊ **Сөткә авызы пешкән мәче шикелле** Уяулык күрсәтеп, саклык белән хәрәкәт итү турында. **Сөтне түккән мәче шикелле** Үз гаебен үзе сизеп, танып, нишләргә белми аптырап тору турында. **Сөттән ак, судан пакь** Бер гөнаһы, гаебе юк; пакь күңелле. *Шушындый иртәнге сәгатьләрдә адәм баласының керле күңеле, кинәт барлык гөнаһлардан арынгандай, үзен сөттән ак, судан пакь итеп хис итә башлый.* И.Гази. *[Таңчулпан:] Үп, сафландыр мине, сөттән ак, кардан пакь булып калыйм.* М.Хәбибуллин. **Сөттән ак, чыныктан пакь** *к.* **сөттән ак, судан пакь**. **Сөттән ару ак кашык** Бик тәрбияле, итагатьле, гаепсез булып кыланучыга карата әйтелә. **Сөт тә юк, йон да юк** Берниндн дә файда, табыш юк; файдасыз

**СӨ́Т АНАСЫ** *и.* Чит баланы имезеп үстергән хатын. *Сөт анасы чакырды, килде Таһир, Бу үткән мөшкелне сөйләде ахыр.* Дастан. *Аны әнкәсе кипшергән күкрәкләре белән туендыра алмыйча гаҗизләнде, бераз үсә төшсә, сөт анасына тапшырырга дип уйлап та куйган, андый хатынны эзли дә башлаган иде.* Ф.Яхин

**СӨ́Т КАРДӘШЕ** *и.* Бер сөт ананы имгән балаларның һәрберсе; имчәктәш

**СӨТЛӘЧ** *с.* Сөтле, сөтне мул бирә торган. *Сулга сикереп, иң юаш, иң сөтләч сыерның сыйрагын тешләде.* А.Гыйләҗев. *Сөтләч кенә бер кәҗә асрармын әле, бөтенләй сөтсез калып булмас.* Г.Якупова

**СӨТЛӘЧБИКӘ** *и. сөйл. к.* **сөтлебикә**. *Ничә еллар буе зур хезмәт куеп, тәрбияләп үстергән сөтләчбикәләрне пычак аша уздыру – иң гади юл, әлбәттә.* Ватаным Татарстан

**СӨТЛӘШ** *и.* Сөттә пешерелгән ботка; сөтле аш

**СӨТЛЕ** *с.* 1) Сөт салынган, эчендә сөте булган; сөткә буялган. *Бераздан теге кызның бик нык эче бора башлаган, һәм, сусызлыкка чыдый алмыйча, теге елан сөтле табакка чыгып чумган...* М.Мәһдиев. *Кулымдагы сөтле чүмечем җиргә төшеп китте.* Татарстан яшьләре

2) Сөтне күп бирә торган; сөтләч. *Үлгәч, әфисәрне түгел, сыерны да,*

*сөтле иде, дип мактыйлар.* А.Таһиров. *Бик тә сөтле кәҗә булып чыга сакалбикә.* Р.Батулла

3) Сөт кушып әзерләнгән, сөттә пешерелгән. *Кичтән калган бер күкәй, искерәк булки белән ак май, бер чәшке куе гына сөтле чәй – завтрак дигәне әлегә менә шул.* Ә.Еники. *Тәлинкәләрнең берсе буш, икенчесендәге сөтле өйрә суынып, өстенә пәрәвез юкалыгы гына җыерчыклы элпә сарылган.* А.Гыйләҗев. *Күрше Гандәлифә әби иртә-кич сыерларын савып, сөтле умач пешереп бирә һәм мичкә ягып чыгып китә.* Н.Әхмәдиев

4) Сөтсыман суты булган. *Җирне тоташ солыча, алабута, сөтле билчән каплап киткән.* Х.Камалов. *--- сөтле үлән һәм билчәннән башка бернәрсә дә үсми торган --- иң ерак төбәктә җир бүлеп бирделәр.* Ф.Әпсәләмова

**СӨТЛЕБИКӘ** *и. сөйл.* Сөтле сыер; савым сыеры; гомумән сыер. *Түгрәнәйдә һәркем танасын Сәхәби үгезеннән аталандырып, аран ишегенә сыймас сөтлебикәләр үстерергә өмет итеп яши иде.* З.Мурсиев. *Быел тана беренче тапкыр бозаулап, сөтлебикәләр дүрткә кадәр җитте.* Шәһри Казан

**СӨТЛЕГӘН** *и. бот.* Сөтлегәнчәләр семьялыгыннан итләч, чәнечке сабаклы, сөтсыман сыекча бүлеп чыгара торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **молочай**. *Сөтлегән (молочай) төрләренең орлыклары, чүп үләне буларак, ашлыкны (икмәкне) агулыйлар.* Ф.Закиров. *Сөтлегән дә очрый, бу – итләч сабаклы һәм ботаклы агачсыман үсемлек, яфраклары юк, чәнечкеләр белән капланган.* Материклар һәм океаннар географиясе

**СӨТЛЕГӘ́НЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Сөтлегән, кәнә үләне, май агачы кебек үсемлекләрне берләштерә торган семьялык

**СӨТЛЕК** *с.* Сөт сатып алу өчен, сөт белән тәэмин итү өчен җитәрлек. *Килешәсездер, җәһәннәм тишегендәге нindидер планетага фәлән миллиард чакрымнар ара узып барырлык космик аппаратлар төзү коточкыч авыр эш кебек. Әмма булдыралар бит! Ә менә Җир йөзендәге һәр балага ипи белән сөтлек акча табылмый.* Татарстан яшьләре

**СӨТЛЕЛЕК** *и.* Сөтле булу дәрәҗәсе. *Сыерның сөтлелеге*

**СӨ́Т-МАЙ** *җый. и.* Сөт белән май; сөт продуктлары. *Сыер уйлап та тормады: – Менә ничек, – ди, – мин, – ди, – хуҗама бик күп сөт бирдем, аның үзен, бала-чагасын сөт-майга мохтаҗ итмәдем, – ди.* Әкият. *Менә нәрсә, әби, син хәзер колхозга кердең инде, без сиңа бу елга сөт-майны колхоздан биреп торырбыз.* Т.Гыйззәт

**СӨ́Т ӨСТЕ** *и.* Савып, күпмедер вакыт торган сөтнең өстендә барлыкка килә торган куе, майлы катлау. *Сөт тә бар, сөт өсте дә, кирәксә, каймак та бар.* Р.Мөхәммәдиев. *Сөмбел өстәлгә яңа пешеп чыккан токмачлы аш, сөт өсте китереп куйды.* З.Кадыйрова

◊ **Сөт өсте каймак, май эче бөйрәк** Сый-хөрмәттә, кадердә яшәүчегә карата әйтелә. **Сөт өстендәге каймак кебек** Карап, кадерләп тоту турында. *Үземне сөт өстендәге каймак кебек саклый алуыма мең кәррә тәшәккер итмәктә идем.* Г.Чыгтай

**СӨТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Сөтне бик аз бирә торган, сөте кимегән яки бөтенләй сөт бирми башлаган (сыер, кәҗә һ.б. тур.). *Сыерыбыз сөтсез булган.* Р.Батулла. *– Сыеры кысыр, сөтсез. – Сөтне күп бирә, тибенми, шәп мал, дип макта, югыйсә сата алмыйсың, – дип киңәш бирә дөнья күргән танышы.* Сөембикә

2) Сөт кушмыйча, салмыйча әзерләнгән, аннан башка пешерелгән. *Көндездән калган ике бәрәңгене тозлап ашыйм, сөтсез, шикәрсез бер чынаяк чәй эчәм ---.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв.* Сөттән башка, сөт эчмичә. *Кечкенә генә авылыбызда бер сыер да калмагач, без дә аны сатарга мәҗбүр булдык. Авылда сөтсез ничек яшәмәк кирәк дип, кәҗә алдык.* Ватаным Татарстан

**СӨТСЕЗЛЕК** *и.* Сөте булмау, сөте югалу (сыер, кәҗә һ.б. тур.)

**СӨ́Т ТЕШЕ** *и.* Баланың биш-алты айлык чагында чыга башлаган, алтыҗиде яшьләрендә төшә торган теше. *Йомшак ипи чәйнәрлек сөт тешләрем чыкты – чын күңелдән сөендем.* Р.Вәлиев. *«Сөт тешләре» дигән төшенчәне беренче мәртәбә Гиппократ куллана. Ул, баланың беренче тешләре ана сөтеннән формалаша, дигән фикердә булган.* Сабантуй

◊ **Сөт теше төшкәнче** Кечкенәдән алып, бик яшьли. **Сөт тешләре дә төшеп бетмәгән** Бик яшь, белем-тәҗрибәсез. *Ә аның, конкрет алып әйтсәк, Мөхәммәди кызының, сөт тешләре дә төшеп бетмәгән.* Ф.Хөсни

**СӨ́ТҮТКӘРГЕЧ** *и.* Ферма, сөт эшкәртү заводы һ.б.ш. урыннарда сөтне күпмедер арага торбалар аша күчерү өчен махсус җайланма. *Әмма бирედә бар да гап-гади: заманча сөтүткәргечләр дә юк, сөтне дә элеккегечә бидоннар белән ташыйлар.* Дуслык

**СӨТЧЕ** *и.* Хуҗалыклардан сөт җыючы; сөт ташучы яки сатучы. *Кая сөтчеләрнең кичәге сводкалары? Күпме сөт булган?* А.Таһиров. *Кабинага кереп утыргач, «сөтче шофёр»ның беренче сүзләре шул була.* А.Тимергалин

**СӨТЧЕЛ** *с.* 1) Сөтле (*2 мәгъ.*), сөтне чагыштырмача күп бирә торган, сөтләч. *Яхшы, сөтчел сыерлар аерым группага тупланды, киләчәктә алар нәсел үзәге булачак.* М.Маликова

2) Сөтле (*3 мәгъ.*), күзәнәкләрендә сөткә охшаш сыекчасы, суты булган. *Көнбагыш чәчәк атып, сөтчел орлыклар барлыкка килгәч, орлык алына, аны иттарткычтан чыгаралар.* Ватаным Татарстан

**СӨТЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының сөт терлеге үрчетү һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Ә калган пионерларыгыз нишли? Илсур белән Таһир сөтчелек фермасында.* Р.Миңнуллин. *[Маннур:] Үзең күреп торасың, сөтчелек белән килеп терәлдек.* М.Хәсәнов

**СӨХБӘТ** *и. гар. кит.* Әңгәмә; гәп, дусларча сөйләшү, аралашу. *Шул газиз Русиянең парланып торган самавыры әтрафында якын яки мәсләктәш кешеләрең белән ачык, самими, шад яки әдәби сөхбәтләргә ни җитә!* Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман

**СӨХБӘ́Т ИТҮ** *ф. к.* **сөхбәт кылу**. *Нәфес бер гүзәл белән дә сөхбәт итүне теләр.* З.Һади. *Туарылып ук дип әйтеп*

*булмаса да, күптәнге танышлар очрашкандагыдай, рәхәтләнеп хәл-әхвәлләр белешеп, сөхбәт итеп утырырга керештек.* Р.Мөхәммәдиев

**СӨХБӘ́Т КЫЛУ** *ф.* Гәпләшеп, аралашып утыру. *Кунакка килгән вакытларда гына күрешеп, сөхбәт кылырбыз.* З.Һади. *Ир-ат сөхбәт кылып утырган өстәл янында тукталмады.* Р.Мөхәммәдиев

**СӨХБӘТЛӘШҮ** *ф. кит.* Сөйләшү-аралашу, әңгәмә алып бару. *Күңел күтәренке вакытта сөхбәтләшү күңелле була.* М.Галәү

**Сөхбәтләшә башлау** Сөхбәтләшергә керешү

**Сөхбәтләшә бирү** Беркемгә һәм бернәрсәгә карамастан, сөхбәтләшүне дәвам итү

**Сөхбәтләшеп алу** Бераз гына, кыска вакыт эчендә сөхбәтләшү

**Сөхбәтләшеп тору** Әледән-әле яки хәзер сөхбәтләшү

**Сөхбәтләшеп утыру** Әле, хәзер, күз алдында сөхбәтләшү

**СӨХБӘТТӘШ** *и. кит.* Әңгәмәдәш, гәпләшеп утыручыларның һәрберсе (бер-берсенә карата). *Гадәттән тыш татлы телле булганы өчен, ул һәрчак минем сөхбәттәшем иде.* К.Насыйри. *Бу яктан караганда, бөтен Борынгы һәм Урта гасырлар --- Г.Тукай белән фикердәш һәм сөхбәттәш булып, татар укучысының колагына һәм күңеленә барып җиттеләр.* Ф.Яхин

**СӨХБӘТЧЕ** *и. кит.* Сөйләшеп-сөхбәтләшеп утыручы, әңгәмәдәш; аралашырга яратучы. *Җор телле сөхбәтче булып чыкты бу иптәш*

**СӨЮ** I *ф.* 1) Иркәләү, назлау, яратуыңны-ошатуыңны белдереп, кочакка алу, күкрәккә кысу, кул белән сыйпау, үбү һ.б.ш. *Битләреннән суыртып, Аркасыннан кагып-кагып сөйсәнә! Җиң очыннан ялгашып, Сөйсәнә, Идегәй, сөйсәнә!* Дастан. *Командир, иелеп, аның [Илсөярнең] иңбашыннан сөеп эндәште: – Тор! – диде ул, көлемсерәп. – Хәзер инде сезнең өйгә кадәр җырлап барырга була.* Г.Гобәй

2) Гадәттә, башка җенестәге кешегә тартылу, аны ошату, ярату, аңа гашыйк булу. *Ләкин күңел сөйгән бер генә, ул бернең унбер мең арасында да булмавы бик ихтимал икән.* Г.Әпсәләмов. *Чибәрләрне сөйдем, сөям һәм сөярмен, Күпме сөеп тоялмамын сөю ямен.* Т.Миңнуллин

3) Ярату, ошату, күңел тарту; өстен күрү. *Сөеп җиккән туры атыңның Дугалары талмы әллә?* Т.Гыйззәт. *Халык каенга шулкадәр сөеп караган ки, аны хәтта манара үзәгенә «алган».* М.Мәһдиев

4) *күч.* Иркәләү, назлау. *Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя...* Ә.Еники

**Сөеп алу** Аз гына, кыска гына вакыт аралыгында сөю. *Яруллин, бая ычкындырган дорфалыгын төзәтергә теләп булса кирәк, әбинең аркасыннан кагып, сөеп алды ---.* Ә.Еники. *Җае чыккан саен, [Нәриман] Зөлфиянең әле аркасыннан, әле беләгеннән сөеп ала.* М.Мәһдиев

**Сөеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта, соңгы арада сөю. *Кыз, китәр алдыннан ат абзарына кереп, атларны карап, сөеп йөри икән ---.* Әкият. *Мин бит әле өйләнмәгән егет, сөеп йөргән кызым да бар...* Г.Әпсәләмов. *Үз кызым дип, шушы туң бүкәннән туган баланы сөеп йөри, аңгыра бәрән.* Ф.Яруллин

**Сөеп калу** Сөяргә өлгерү. --- *аның күңел түрендә кабат татлы, ләкин гөнаһлы теләк кымырҗый башлады: «Әллә бар нәрсәгә кул селтәп, бер яратып, сөеп, татып калыргамы соң бу гүзәлне?»* З.Мәхмүди

**Сөеп карау** Сөяргә омтылу, сөяргә тырышу; бер мәртәбә сөю. *Аның әле чын-чынлап сөеп тә, үлеп тә караганы юк...* Г.Гыйльманов

**Сөеп кую** Кинәт, көтмәгәндә, башыннан яки аркасыннан сыйпап, бер мәртәбә сөю. *– Барыгыз, балам, барыгыз, – дип, Рәхимә җиңги дә яраткан килененең аркасыннан ук сөеп куйды.* М.Мәһдиев. *Әни аркамнан сөеп куйды шунда.* Р.Мөхәммәдиев

**Сөеп тору** Әле, хәзерге вакытта сөю; даими сөю. *Ул аның башыннан сөеп торды ---.* Х.Камалов

**Сөеп чыгу** Барысын да бер-бер артлы сөю; бөтен җирен сөю. *Гөлфия балакай изоляторда икән, барлык балаларны бер сөеп чыкканнан соң, аның янына чаптым.* Ф.Яруллин. *Нәфисә, сакал-мыекларын төзәткән булып, юындырган, коендырган булып, тагын бер мәртәбә Хәлимнең бөтен җирен сыйпап, иркәләп, сөеп чыкты.* Г.Гыйльманов

◊ **Сөеп алган, сөеп барган** Элек кыз алуны коры мәһәр түләүгә генә кайтарып калдырмыйча, чын мәгънәсендә сөеп өйләнү, сөеп кияүгә чыгуның изге гамәл булуы турында. *Биек тауның башында Яшел үлән зәрдәсе; Сөеп алган, сөеп барган Бер Ходайның бәндәсе.* Җыр. **Сөйгән бәндәсе** Бәла-казалардан җиңел генә котылучы кешегә карата әйтелә. *Ничә бәладән башы исән чыкты, сөйгән бәндәсе.* Г.Монасыйпов. *Ходай чирне дә, сынауларны да сөйгән бәндәсенә бирә ---.* Ватаным Татарстан. **Сөймәгәнгә сөйкәнү** Үзеңне яратмаган кешегә ошарга тырышу. **Сөймәс сөяк** *к.* **сөйкемсез сөяк**. *Ихтимал, сөймәс сөяк булганга шулай күралмагандыр. Мин бары иремнән, якын туганнарым кулыннан гына бүләк алам, дип баш тартты әлеге затлы балдактан.* М.Әмирханов

**СӨЮ** II *и.* Мәхәббәт, гыйшык, ярату. *Гөлем сыгылып төште бит – Чәчәкләре көчле бик. Әй бу сөю! Минем хәл дә Шул гөл хәле төсле бит.* Х.Туфан. *Язам дисәң, кырларың бар, Җырлыйм дисәң, җырың бар. Тик син гел сөю җырлыйсың – Әллә инде күңелең тар, Әллә, чынлап, ярың бар?!* Р.Вәлиев

**СӨЯК** *и.* **1.** 1) Кеше яки хайван скелетын тәшкил иткән каты тукыма. --- *Мамадыш өязендә Теләче карьясендә тау җимерелеп, җирдән гаять олуг адәм сөякләре табылган, имеш.* К.Насыйри. *Йосыфның йөзеннән кан качты, яңак сөякләре бүлтәеп чыкты, сулышы өзелеп-өзелеп алды, кан басымы бер өскә сикерде, бер төшеп китеп югала язды.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Нык ябыккан кеше, хайван, аның арык тәне. *Мин сап-сары, коры сөяк инде, Шул көрәшләр төенен тик санап, Үпкә черекләрен тәкерә-тәкерә, Караватта ятам, сызгалап.* М.Җәлил. *Тик, кызлар, сарык түшкәсеннән өлеш көтмәгез, Фәрнәснең терлекләре ябык,*

*карга чукырлык итләре юк, шыр сөяк.* Н.Гыйматдинова. *Ә Бикҗан ябык, бөтен тәне сөяк кенә!* М.Шаһимәрдәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Сөяктән яки сөяк катнаштырып эшләнгән; сөяктән алынган. *Һәвәскәр тарихчы Марселино де Саутуола 1879 елда --- таштан ясалган эш кораллары, сөңге очлары, сөяк энәләр, кабырчыклардан эшләнгән бизәнү әйберләре таба.* Г.Дәүләтшин. *Рәхәт иде мәгәр! Капрон оек бәясенә сатып аласың да, җилкәсендәге погон кебек чүпрәкләрен сүтеп ташлыйсың да елтыр сәдәфләрен сөяк төймәләргә алыштырасың и вәссәлам! Биш-алты ел буе киемең бар дигән сүз.* Ф.Баттал

2) Сөяктән торган, сөяк тәшкил иткән. *[Искәндәр] Каз бибиен битенә якын китергәч, үлән исе килеп торган сөяк борыны белән биби аның иренен чукый, колак яфрагын кабып карый.* М.Мәһдиев. *Тиресе сөяк пластинкалардан торганлыктан, аны [крокодил] дошманнары куркытмый ---.* Т.Шакирова

3) *күч.* Нык ябыккан, арык. *Бу юлы Нәҗип түзмәде, башын читкә борып, күзен яшереп, әткәсенең шыр сөяк җилкәсенә кулын салды.* А.Гыйләҗев. *--- Имәнлек урманының бүген бер яфраксыз калган шәрә кәүсәләре миңа Маутхаузен, Освенцим концлагерьларында мунча кертелгәннән соң, киенделмичә, суыкта тотылган тере сөяк әсирләрне хәтерләтте. Йөрәк чәнчеп куйды.* А.Хәлим

◊ **Сөяген көл итү** Үтереп, юк итү. **Сөяген үзгәртү** Элегрәк, гадәттә, сатылмый калган товарны, кире өйгә алып кайтмас өчен, башка бер товарга алыштырып сату итү турында. **Сөяк белән тире** *к.* **сөяк тә тире**. *Инде ишекнең теге ягында – икенче дөньяда яшәүчеләрне күзәтик, --- һәммәсе дә артык дәрәҗәдә ябыклар, тәннәрендә сөяк белән тиредән башка бернәрсә булыр дип уйларга да мөмкин түгел.* Д.Заһидуллина. **Сөяк булып кадалу** Бик вакытсыз мәшәкать, уңайсызлык тудыру, нык борчу, ризасызлык уяту турында. *– Мине кабул итмәде, кәгазьләремә кул куймады теге чукынчыгы. – Димәк, син бугазларына сөяк булып кадалгансың.* Т.Галиуллин. **Сөяк йомшарту** 1) Тәндәге авырлык, арганлык халәтен киметү яисә бетерү максаты белән физик күнегүләр ясау, мунча керү һ.б.; 2) Исерткеч эчемлек эчеп, тәндәге арганлык, авырлык халәтен китерү. *Бик соң кайттык, шуңа күрә бераз сөякләрне йомшартмый булмады. Беләсең бит, безнең эш авыр.* А.Расих. **Сөяк йомшату** *к.* **сөяк йомшарту**. *Ваннада сөякләрне йомшатып чыккач, балалар белән бер чүкердәшеп чәй эчүләре ни тора бит.* М.Хәсәнов. **Сөяккә калу** Нык ябыгу. **Сөяккә үтү** Нык чылану яки туңу турында. *Мин тәрәзә төбенә ятып егладым, егладым. Салкын яңгыр бөтен сөягемә үткәнгә кадәр. Мин теге хатын киткәнен көттем.* Г.Исхакый. **Сөяк күргән эттәй** Ашыгыпашкынып, зур түземсезлек белән. *Теге түти дә әнә шундый койты ният белән, сөяк күргән эттәй, керләр арасыннан Мөбарәккә үрелеп-үрелеп карады.* М.Шаһимәрдәнов. **Сөяк патшасы** Зур гәүдәле, ябык кеше. *Ул [Вәли] бик зур гәүдәле булып, үзе какча булганга, крушниклар аны сөяк патшасы дип йөртәләр иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Сөяк салу** Фал ачу, күрәзәлек итү. *– Тынычлан, утыр! – диде сихерче карчык. Көчсез, ләкин кырыс тавыш белән: – Хәзер мин сиңа сөяк салам. Киләчәгеңне әйтәм, – дип өстәде.* Р.Сәгъди. **Сөяк-сандырагын ватмый гына йөрү** Бөгелми-сыгылмый, сынын артык туры тотып. **Сөяк сарае** *к.* **сөяк патшасы**. **Сөяк тә җан** *к.* **сөяк тә тире**. *Бөтенләй хәлсез, буынсыз иттеләр. Сөяк тә җан гына калды. Сөйләшеп булмас инде, ачуланма. Хәлләр бик мөшкел безнең.* Г.Гыйльманов. **Сөяк тә тире**. Үтә дә ябык кеше. *[Шәйхетдиннең]--- әзмәвер кебек адәмнән сөяк белән тире генә калган, карачкыга әверелгән гәүдәсе атлаганда чайкала, җил иссә, аягында басып кала алуы да шикле иде.* Н.Әхмәдиев. *Малай җиңел иде, сөяк тә тире генә, барлыгы да беленми. Әмма аның арык тәненнән шундый кайнарлык бәрә, хәтта картның аркасын пешерә башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Шулкадәрле күп эштән ул [генерал Антонов], ябыгып, какчаланып, сөяк белән тирегә генә торып кала.* З.Зәйнуллин. **Сөяк уены** Ян якларына кыеп ясалган һәр ноктасы аерым бер сан урынына йөргән шакмакчыкларны өстәл өстенә тәгәрәтеп җибәреп, очко җыюдан гыйбарәт комарлы уен төре; шакмаклы уен. *Базарда сатучы ирләр көннәрен сөяк уены уйнап үткәрәләр.* **Сөяк уйнау** Сөяк уенында катнашу. *Сәет узгынчылар белән көн дә диярлек сөяк уйнамаса, бөтенесе яхшы бара иде. Беркөнне уен вакытында Кыпчакбай кешеләре Сәетне эләктереп алганнар.* Т.Галиуллин. **Сөяк утырту** Тайган сөякне кире үз урынына утырту. *Ул үз тәҗрибәсеннән чыгып белә: сөяк утырту алай ук җиңел эш түгел.* Ф.Яруллин. **Сөяк утыртучы** Тайган сөякне кире урынына утырту белән шөгыльләнүче кеше. *Аннары им-томчы дигәннәренең гап-гади бер сөяк утыртучы сукыр карчык икәнлеген белгәч, бөтенләй тынычланды.* Ф.Яруллин. **Сөяк шыгырдату** Массаж ясау. *Олы, тигез сәке төсле махсус станга җәеп салып, ике-өч сәгать интектерә Кәримне татар фамилияле абзаң. Без бит массажны сөяк шыгырдату --- дип кенә күз алдына китерәбез.* Т.Галиуллин. **Сөяк эчендәге җелек кебек** Кадерләп тору турында. **Сөяк язу** *к.* **сөяк йомшарту**

**СӨЯКЛӘНҮ** I *ф.* 1) Сөяк хәленә килү, сөяккә әйләнү; сөяк булып катылану. *Кимерчәк сөякләнү*

2) Нык кату, катылылыгы белән сөяккә охшаш хәлгә килү

3) *күч.* Җанлылыгын югалту, төссезләнү. *--- төнлә, вакытсыз, кемнәндер качып суелган сарыкларның күзләре ай яктысында якут ташы кебек зәңгәрләнеп сөякләнгән иде.* А.Хәлим

**Сөякләнә бару** Торган саен ныграк сөякләнү

**Сөякләнә башлау** Сөякләнү билгеләре күренү. *Атлантның алгы җәясе туганнан соң беренче айларда сөякләнә башлый һәм урта атлант – төп сөяк буынны тикшерүгә комачаулый.* Фән һәм тел

**Сөякләнеп бетү** Тулысынча сөякләнү. *Эскәмия димәктән, инде биш еллап яткан, сөякләнеп беткән имән агачы иде ул.* Ф.Яхин

**Сөякләнеп калу** Нindидер тәэсирдән соң сөякләнү

**СӨЯКЛӘНҮ** II *и.* Сөяк хәленә килү, сөяккә әйләнү, сөяк булып катылану процессы. *Сөякләнүнең икенчел нокталары туганнан соң барлыкка килә.* Фән һәм тел

**СӨЯКЛӘЧ** *с. к.* **сөякчел**. *[Командующий] өстәлдәге Казан шәһәре планына бармак буыннарының сөякләч сырты белән төртә-төртә, кайсы төбәккә нинди көчләр беркетелгәнен әйтте.* К.Нәҗми. *Әби сөякләч куллары белән мине этебрәк җибәрде: – Син бар, уеныңда бул!* ---. Г.Бәширов

**СӨЯКЛӘЧЛӘНҮ** *ф. к.* **сөякчелләнү**

**СӨЯКЛӘЧЛЕК** *и. к.* **сөякчеллек**

**СӨЯКЛЕ** *с.* 1) Сөяге булган, сөяктән арындырылмаган; сөяге күп булган. *Йомры-йомры бәрәңге белән сөякле тавык кимерер идем.* Н.Гыйматдинова. *Сөякле балыкларныкыннан аермалы буларак, аларның саңак капкачлары юк, һәм саңак ярыклары мөстәкыйль тишемнәр белән тышка ачыла.* Биология

2) *к.* **сөякчел**. *Бабасы сөякле куллары белән, ашыга-ашыга, аның битләреннән сыйпый* ---. Р.Вәлиев. *Нәфисә әби, авызын сөякле учы белән тоткан килеш кенә, уңы-сулына карап алды* ---. Ф.Яхин

**СӨЯ́К-САНАК** *җый. и.* 1) Җанлы организм тәнендәге сөякләр. *Карт сөякләр сызлап тора, яңгыр килгәнен сизә сөяк-санак.* Р.Батулла. *Аның исән калуы, чыннан да, могҗизага тиң иде: --- баш-йөз ярылган, сөяк-санак сынган, эчке әгъзалар имгәнгән...* Ф.Бәйрәмова

2) Күбрәк сөякле булган, гадәттә түбәнрәк сыйфатлы ит кисәкләре. *Сөяк-санак өелгән табакның күз алдыннан югалуы булды, аның урынына икенче табак белән икенче ал санны китереп, тагын хан алдына сузып салдылар.* Н.Фәттах. *Күз алдына китерегез: башкала урамында – асфальттта – газ баллоны белән икешәр плитә тора, кәстрүлнең зуррагында сөяк-санак кайный: шулпа пешә* ---. Сөембикә

3) Табыннан калган яисә әллә кайчан ташланган сөякләр, сөяк калдыклары. *[Археологларның тирәсендә] кирпеч ватыклары, чүлмәк кыйпылчыклары, кибеп беткән сөяк-санаклар.* М.Госманов. *Гомер эт яратмаган карчык-корчыклар да Казбекка сөяк-санак китерә* ---. М.Галиев

**СӨЯ́К-САЯК** *җый. и. к.* **сөяк-санак**. *[Дворник:] Сөяк-саяк авыртып, йокыдан бик авыр торган идем.* М.Гали

**СӨЯКСЕЗ** *с.* 1) Сөяге булмаган яки бик аз калган; сөягеннән аерып алган. *Ә менә мин көтүдән кайтуга аш кирәк булыр: борчак ашы ятатам, сөяксез итне ваклап турап сал, һәм дә итең майлы булсын.* Р.Газиз. *Бер-ике сәгать ял итеп һәм ашап алгач, поши түшкәсенең сөяксез генә җирләрен кисеп алып, күтәрә алганчы ит алдылар да кайтырга чыктылар.* И.Хуҗин

2) *зоол.* Скелетлары кимерчәктән торган; кимерчәкле. *Сөяксез балыклар*

3) *күч.* Бик сыгылмалы гәүдәле, бөгелүчән, сыгылучан; хәрәкәтчән. *Минем гәүдәм сөяксез дип әйтергә була, әллә нинди торышларга кереп бетә алам, ди.* К.Җәмит

◊ **Сөяксез тел** *шелт.* Чамадан тыш күп сөйләшергә, еш кына буш, юк-бар сүз сөйләргә яратучы кеше турында. *Сөяксез тел ниләр сөйләмәс. Вәгъдәләрне күпме бирсәләр дә, Читләр килеп безне көйләмәс.* Н.Әхмәдиев. *Тел сөяксез инде, гел сөйләр.* Ф.Яхин. *Мәчет төзүче егетләрнең җиңел аягы, сөяксез теле белән хәбәр халыкка бик тиз таралды.* Г.Мирһади

**СӨЯКЧӘН** *с. сир. к.* **сөякчел**. *Сөякчән кул*

**СӨЯКЧӘНЛЕК** *и. к.* **сөякчеллек**. *Бала үзенең сөякчәнлеге белән башкалардан аерылып тора*

**СӨЯКЧЕ** *и. махс.* 1) Сөяк-санак (*3 мәгъ.*) җыючы, әзерләүче

2) Сөякне кырып, уеп бизәүче, сөяктән сәнгать әсәре эшләүче. *«Тубылга барабызъ» дигән сүз чыгуга ук, сөякче Минсәлим Тимергалиевны күрмичә кайтма, дигәннәр иде.* Ватаным Татарстан

**СӨЯКЧЕЛ** *с.* Бик ябык, чандыр, сөякләре нык беленеп торган. *Имән бармагына тишекле-тишекле уймак кигән сөякчел кулы елт-елт итеп тукыма кисәге өстендә йөри.* М.Галәү. *Менә шунда гына исемә килеп, тирләп-пешеп, Галимҗан аганың сөякчел, салкын кулларын кыстым.* И.Салахов

**СӨЯКЧЕЛЛӘНҮ** *ф.* Сөякчелгә әйләнү. *Кул сөякчелләнү*

**Сөякчелләнә бару** Торган саен ныграк сөякчелләнү

**Сөякчелләнә башлау** Сөякчелләнү билгеләре күренү; сөякчелләнүгә таба йөз тоту

**Сөякчелләнеп бетү** Тулысынча сөякчелләнү

**Сөякчелләнеп калу** Нindидер сәбәптән яки күпмедер вакыт узгач сөякчелләнгән хәлгә килү

**Сөякчелләнеп килү** Акрынлап, азазлап сөякчелләнү

**Сөякчелләнеп китү** Кинәт кенә сөякчелләнү, ябыгып калу

**СӨЯКЧЕЛЛЕК** *и.* Сөякчел булу; ябыклык, чандырлык

**СӨЯЛ** *и.* 1) Тире өстенә үсеп чыккан каты төер; челги; *русчасы:* **бородавка**. *Чыккан сөял сызлап куя сулык-сулык.* Р.Харис. *Вәфия әби чуан, тимрәү, сөял ише авыруларны да «үз ысулы» белән юып алгандай итә.* Сөембикә

2) Озак эшләү яки ышкылу һ.б.ш.дан аяк-кул тиресенең кабарынкы булып катыланган урыны; *русчасы:* **сухая мозоль**. *Бәхет тапкан гади эшчеләр, Икесе дә – көн дә иртә торып, Кичкә чаклы учта сөял уып, Тормыш төзи торган кешеләр.* Г.Афзал. *Әгәр дә җитдирәк караганда, уң кулыгызның урта бармагындагы сөял сезнең күп яза торган кеше икәнлегегезне сөйли.* Р.Батулла

◊ **Сөялгә басу** Берәүнең күңеленә тия торган, аеруча борчыган ягына кагылу, берәр кимчелегенә ишарәләп төртмә сүз әйтү. *Бу соравы белән Сәфәргалинең сөяленә баскандай итте.* Ф.Хөсни. *Тормыш укымаган кешенең сөяленә бик тиз баса.* Г.Әпсәләмов. *Дөнья баса сөялгә.* Ф.Җамалетдинова

**СӨЯЛДЕРҮ** *сөйл. к.* **сөяү**. *– Эчмәсен дип, Гаяныңның артыннан йөрисең дә, ул булмаса нишләр идең соң син, чак тәре? – дип, Хәят апаны шап итеп коймага сөялдерде Түтүт.* Р.Газиз

**СӨЯЛЛӘНҮ** *ф.* Сөяллегә әйләнү, сөялләр чыгу. *Ул элеккечә сөялләнеп*

*каткан куллары белән, --- уңышның бөртеген дә әрәм итмәскә тырышып кадерләп җыя.* С.Җәлал. *Аңарчы әле синең бөкрең чыгар, тез башларың сөялләнеп катар, төннәрне йокысыз уздырып, күзләрең чепиләнер.* Г.Бәширов

**Сөялләнә бару** Торган саен күбрәк сөялләнү

**Сөялләнә башлау** Сөялләнү билгеләре күренү. *Һәм ул күп уйнаудан сөялләнә башлаган имән бармагы белән, оста гына итеп, Йосыфның соңгы шашкасын тактадан чиертеп төшерде.* А.Гыймадиев

**Сөялләнеп бетү** Тәмам сөялләнү. *Гатаулла буыннары сөялләнеп беткән тупас бармаклары белән сакал астын кашыды.* А.Расих. *Азаматның төрле кибетләрдә грузчик булып эшләп сөялләнеп беткән бармаклары гитара кылларын чиртте...* Р.Ахунова

**Сөялләнеп калу** Нindидер эшсәбәптән соң сөялләнгән хәлгә килү. *Сөялләнеп калган учында яра эзе күренеп тора.* Мәдәни җомга

**Сөялләнеп киту** Кинәт сөялләнү. *Биек үкчә киеп йөрүдән барлыкка килгән проблемаларга аяк тиресенең кайбер урыннары катып, сөялләнеп китүе, шешенүләр өстәлә.* Кәеф ничек?

**СӨЯЛЛЕ** *с.* Сөяле булган, сөял чыккан. *Васфикамал Хәкимулланың кытыршы, сөялле кулларын үзенең яңагына куеп яшь сыкты ---.* М.Мәһдиев

◊ **Сөялле кул** Эшче, хезмәт иясенә карата. *Сарайларны балалар йортларына һәм сөялле кулларның ял итү йортларына әйләндерү юлында --- асылган революционерлар искә төште.* М.Максуд

**СӨЯЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сөяү**

2) Берәр нәрсәгә яки кешегә якын килеп яисә утырып, гәүдәнең югарыгы өлеше белән аңа терәлү, таяну. *Капка баганасына сөялдем дә йөзем белән Зәңгәр чишмәгә әйләндем.* Г.Ибраһимов. *Өйалдының ишек яңагына алама гына соры күлмәк кигән бер яшь кызый килеп сөялде ---.* Г.Бәширов

**Сөялә төшү** Беркадәр, бераз сөялү; тагын да ныграк сөялү. – *Калҗа, марҗа һәм эчәргә бер баржа, – диде ул, урындыкка сөялә төшеп.* Р.Мөхәммәдиев. *Зоя аптырабрак калды, диванга сөялә төште, сигара суырып утырган Роллингка күз төшереп алды да язуны укып чыкты ---.* А.Толстой

**Сөялеп калу** Сөялергә өлгерү; нindидер тәэсирдән соң сөялү. *Менә бүген дә, эштән кайтып барганда, аяк астында җир убылгандай булды, бер коймага гына сөялеп калды.* З.Кадыйрова

**Сөялеп тору** Әле, күз алдында, хәзер сөялү; һәрвакыт сөялгән хәлдә булу. *Аның артындарак чүпрәккә төрелгән озын бер нәрсә стенага сөялеп тора иде, шуңа ымлап сорадым ---.* Ә.Еники. *Ике тәүлек имәнгә сөялеп торган бурлы бия тере калды.* З.Зәйнуллин. *Сулы чиләген кар өстенә куеп, озак кына капка баганасына сөялеп торганын хәтерли ул тагы үзенең.* Р.Мөхәммәдиев

**СӨЯ́Л ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан дару үләне буларак кулланыла торган сары чәчәкле берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **бородавник**. *Идел һәм Урал буе флорасы алкалоидлы үсемлекләргә бай: аюмабан, камчат чәчкә, сөял үләне, елан көпшәсе һ.б.* Ботаника

**СӨЯМ** *и. иск.* Аршынның чирегенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге; карыш (≈ 17 см). *Сиксән сөям сөңгене Селтәмәстән кулга алып, Мөйтәннән туган Кыпчак би Чыга куйды гөрс итеп!* Дастан. *Аның бер-бер бармагы берәр сөям буйлыгы; тырнаклары берсе-берсе адәм бармагы буенда була.* Легенда. *Бабасы, улың бер сөямгә үскән бит быел.* Д.Каюмова

**СӨЯМЛЕ** *с. иск.* Сөямнәргә бүленгән, сөямнәр белән үлчәү өчен яраклаштырып эшләнгән. *Бу турыда бит агым ай-яй кызу! Су төбендә ком түгел таш чыдамый. Бүтән берәү булса, сөямле таяк белән үлчәп йөрер иде.* К.Нәҗми

**СӨЯН** *и.* **1.** Кабыгы төшерелгән юкә бүрәнәсе. *Сөялдем сөяннәргә, тирбәлдем имәннәрдә, Бар шатлыгымны бирәмен Кадерен белгәннәргә.* Ф.Яруллин. *Безнең авылда әле дә кабартмаларны – ак чыршы утыны, коймакны тал чыбыгы, сөян, зирек утыны ягып пешерәләр.* Г.Гыйльманов. *Сөян агачыннан рәшәткә ясап, чардуган куйдык.* Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кайрысы, кабыгы төшерелгән. *Үзенең трусикчан гына йоклавы да, сөян бүрәнәләрдән килгән испнең күздән яшьләр атылып чыгар дәрәҗәдә таныш булуы да --- гаҗәп һәм куркыныч иде.* Ә.Гаффар

2) Шундый бүрәнәдән салган, эшләгән. *Сөян бура. Сөян терәү кую*

3) Шундый бүрәнәне ярдырып эшләгән, алынган. *Сәке белән сандык арасында буяусыз, сөян тактадан ясалган аксак өстәл.* М.Юныс. *Урман хуҗалыгыннан яздырып алган сөян такта бетмәгән иде әле.* Р.Мөхәммәдиев

**СӨЯРКӘ** *и. хурл.* Өйләнешмичә, әхлак-әдәп нормалары белән исәпләшми җенси мөнәсәбәттә торучы ир яки хатын. *Җил аны өенә – хатыны янына кайтара, я сөяркәсенә илтә.* М.Маликова. *Аның эшеннән китәчәген әле хатыны да, балалары да, җан кисәккәе – сөяркәсе дә белми иделәр ахрысы.* Ф.Яхин

**СӨЯТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **сөяү**. *Анда Субра җырауны Биленә пута будырып, Яңакларын бәйләтеп, --- Алтынлы көймәгә менгезеп, Култыгына җизле таяк сөятеп, --- Ханга алып киттеләр.* Дастан

**СӨЯ́Ү** *ф.* 1) Озынча нәрсәне, авып төшмәсен өчен, югарыгы ягы белән берәр нәрсәгә терәп кую. *Мирзахан, мылтыгын стенага сөяп, айгырның муенын кочып, маңгаен сыпыра.* С.Зыялы. *Сәкинә бәрәңге бакчасы аша үтте, арткы капканы ачып керде, тырмасы белән сәнәген лапас ышыгына китереп сөяде ---.* Ә.Әминов

2) Ышыклау-каплау максаты белән нәрсәнедер икенче бер әйбергә терәтеп кую. *Төнлекне япты, кояш карамаган якларның киезләрен бөтенләй күтәреп, өч яктан кирәгәләргә челтәрләрне сөяде.* Г.Ибраһимов. *Лапас авызына кабык сөяү. Абзарның җил үтәрдәй ярык турыларына такта сөяү*

3) Баскан яки утырган хәлдә гәүдәне берәр җиргә терәү. *Автомобильнең йомшак урындыгына аркаларны сөяп, янган немец танклары, атылган гильза әрдәнәләре яныннан тылга таба чапканда, майорның ышанычлысы сорашып барды ---.* И.Гази. *Илдар Маннанов,*

*орудие лафетына башын сөяп, туңган җиргә яткан.* Р.Могыйнов

**Сөйи башлау** Сөяргә тотыну

**Сөяп кую** Сөялгән хәлгә китереп калдыру. *Гөлчирә: «Үзем барам...» – дип йөгереп төшеп, шалашка сөяп куйган ишкәкләрне ала.* М.Җәлил. *Ул --- Флүр Сәхәбиевичның стенага сөяп куйган гитарасын үрелеп алды.* Р.Кәрами

**Сөяп тору** Даими сөяү. *Юнылмаган иске таяк аның үз буе кадәр диярлек, һәм ул аңар, таянудан бигрәк, алга авышкан гәүдәсен терәү, сөяп тору өчен хезмәт итә иде күрәсең.* Р.Мөхәммәдиев

**СӨЯҮЛЕ** *с.* Сөяп куелган. *Сөяүле көрәкне аудару*

**СПАЗМ** *и. гр. мед. к.* **спазма**. *Син үзең истериягә бирелмәгәнсең, ә тамагыңа истерик спазм булган. Тамак сеңерләрең, кыскарып, --- азык үткәрә торган юлны буган.* А.Шамов

**СПА́ЗМА** *и. гр. мед.* Очлык яки куыш орган мускулларының ирексездән тартышып кысылуы, киерелүе. *Әле башы авыртудан, әле эчәкләрендәге спазмалардан зарланучы әти белән, әлбәттә, озаклап сөйләшеп утыра алмый [улы].* Ф.Хөсни

**СПА́ЙКА** *и. рус мед.* Әгъзаларның эшчәнлегенә зыян китерә торган, тукымаларның тумыштан яки яралану, ялкынсыну нәтиҗәсендә барлыкка килгән тоташуы, керешүе

**СПА́РЖА** *и. фр. бот.* 1) Әспечәләр семьялыгыннан тамыры һәм яшь бәбәкләре халык медицинасында кулланыла торган күпьеллык үләнчел үсемлек; әспе, чебен үләне. *Әспечәләр семьялыгына кергән үсемлекләрнең кайберләре, мәсәлән, яшелчәләрдән спаржа, сарымсак --- культуралы үсемлекләр булып әверелгәннәр.* Декоратив үсемлекләр. *Шуңа да спаржа тромблар барлыкка килүне булдырмый торган табигый дару булып тора.* Шәһри Казан

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы тамыры

**СПАРТАКИА́ДА** *и. рус* Киң массалар катнашында спортның күп төрләре буенча үткәрелә торган зур ярыш. *Быелгысы Яшьләр көненә туры килгәнлектән, «Иләбәрдә спартакиада була икән» дигән хәбәр дә яшен тизлеге белән таралды.* Т.Нәҗмиев

**СПАРТАКИА́ДАЧЫ** *и.* Спартакиадада катнашучы

**СПА́РТАЛЫ** *и. к.* **спартан**

**СПАРТАН** *и. гр.* **1.** 1) Борынгы Грециядә Спарта дәүләте гражданы

2) *күч.* Үзен авыр шартларда, мохтаҗлыкта яшәп чыныктыручы, тормышта иң аз һәм иң кирәк нәрсәләр белән генә чикләнүче кеше. *Табигать мине тумыштан ук спартан итеп барлыкка китергән, күрәсең.* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Спарталы кебек нык, чыныккан, батыр

2) Авыр, кырыс, кыенлыклар тулы. *Бертуган абзыем, --- энесен спартан рухта тәрбияләргә тырышуданмы (һәрхәлдә, мин моның явызлыктан, күңел тупаслыгыннан түгеллегенә иманым камил), минем китап укып утыруымны ифрат та яратмады.* А.Хәлим. *Спартан шартларда яшәү*

**СПАРТА́НЧА** *рәв.* Спартаннар кебек, бик кырыс шартларда, бернинди йомшаклык булмыйча. *Спартанча яшәү. Спартанча тәрбияләү*

**СПЕКТАКЛЬ** *и. фр.* 1) Драма әсәре буенча куелган сәхнә тамашасы, театрда куела торган уен. *[Гаяз:] Җәй көне дә бер спектакль куя алырбыз бит әле.* М.Әмир. *Казанга кайтуга, Ленар аз булса да үзеннән туйга өлеш кертү нияте белән театрга китте: соңгы спектакль өчен аласы гонорарлары бар иде.* И.Сиражи

2) *күч.* Гомумән берәр ягы белән җәлеп итә, кызыксындыра торган күренеш, вакыйга, тамаша. *Шулай да ул бильярд уенының шар сугу гына түгел, ә нәни бер спектакль, үзе бер сәнгать икәнлеген онытып җибәрми.* М.Галиев. *Икенче бер олпат әдип белән, әйтик, Мәгъсүм ага Хуҗин белән, Ризван Хәмиднең гәпләшүе – үзе бер спектакль.* Л.Лерон

3) *күч.* Ялгыш фикер тудыру яки башка максат белән башкарылган ясалма сөйләш, кыланыш, үз-үзеңне тотыш. *Димәк, «спектакль»: кәмитләнә болар. Янәсе, сынап карарга кирәк: нindирәк кеше икән яңа замполит. Усалмы, хәйләкәрме?* С.Шәрипов

**СПЕКТР** *и. лат. физ.* 1) Берәр система яки процессны характерлаган физик зурлыкның барлык күрсәткечләре. *Тирбәнешләр спектры. Тавыш спектры*

2) Яктылык нуры призма аша үткәндә барлыкка килгән төсләр рәте. *Нурланыш спектры. Кояш спектры* // Кызган җисем яки матдәнең нурланышы махсус оптик приборлар аша үткәндә барлыкка килә торган төсләр тасмасы. *Водород спектры*

3) *күч.* Берәр күренеш, сыйфат һ.б.ш.ларның мөмкин булган барлык төрлелеге, киңлеге, диапазоны, колачы. *Шулай итеп, сәяси спектр Кремльнең курчак партияләре тарафыннан бүген тулысынча колачлана.* Ф.Уразай

**СПЕКТРАЛЬ** *с.* Спектрга мөнәсәбәтле; спектроскопия белән бәйле. *Спектраль анализга килсәк, моны яклаучылар металл әйберләрнең спектрларын тикшерү дәвамында аларның составын --- гына түгел, шул металл әзерләгән руданың кайдан табылып, кайчан эшкәртелүен өйрәнә икән.* М.Госманов. *Спектраль анализ – матдәне сыйфат һәм сан ягыннан анализлауның физик ысулы.* Төзү материаллары

**СПЕКТРОГРА́ММА** *и. лат.-гр. физ.* Спектрның фоторәсеме

**СПЕКТРОСКОП** *и. гр.* Спектрны визуаль күзәтү өчен ясалган оптик прибор. *Аннан алган газларны тикшердем: пыяла ретортага җыеп, аның аркылы электр яктысы үткәреп, газ аша узган нурларны спектроскоп призмасында таркатып карадым...* А.Толстой

**СПЕКТРОСКО́ПИК** *с.* Спектроскопка, спектроскопиягә мөнәсәбәтле. *Спектроскопик тикшеренүләр*

**СПЕКТРОСКОПИ́Я** *и. лат.* Физиканың электромагнит нурланыш спектрларын өйрәнә торган тармагы. *Парамагнитик резонанслар, спектроскопия алымнары – күптән үтелгән этап.* Р.Зарипов

**СПЕКУЛЯ́НТ** *и. нем.* Спекуляция (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче. *Аны горпромторгның оятсыз спекулянтлары, кимсетеп, өстеннән аноним хатлар язып бәгырен кимереп тордылар.* Г.Ахунов

**СПЕКУЛЯНТЛЫК** *и.* Спекулянт кәсебе, шөгыле. *Авыл белән шәһәр арасында ит белән спекулянтлык итә.* Т.Гыйззәт. *Ничек кенә булса да, Котласның һичнигә бирешми, пошынмый, кичә үзе спекулянтлыкта гаепләп кәнсәләргә бикләп куйган хөкүмәт вәкилләренә дә --- шаркылдап көлеп сәлам биреп --- яшәп яткан көне.* Т.Гарипова

**СПЕКУЛЯТИВ** *с. кит.* 1) Спекуляциягә (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтле, шуңа нигезләнгән. *Спекулятив бәяләр*

2) Спекуляциягә (*2 мәгъ.*) нигезләнгән. *Спекулятив алымнар. Спекулятив сәясәт*

3) Асылы спекуляциягә (*3 мәгъ.*) кайтып калган, абстракт

**СПЕКУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Җиңел табыш алу өчен, товарларны, арзан бәядән сатып алып, кыйбатрак бәягә сату эше. *Кулаклар икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә, аеруча үзәктә, икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр.* М.Җәлил. *Ә байлар халыкның үз икмәген үзенә ун бәясенә сатып, спекуляция белән шөгыльләнеп яталар.* В.Нуруллин

2) Берәр нәрсәне үз файдасына бору, нәрсәдәндер файдалану нияте. *Танышлар, дуслар арасына керү генә җитмәгән, инде сабыйлар исеме белән спекуляция ясый башладылар.* А.Әпсәләмова

3) Фактлар белән дәлилләнмәгән, коры фаразлауга нигезләнгән фәлсәфи хөкем. *Монда партиясезләр артты-рыбрак та җибәрделәр. Идеологик спекуляция белән дә шөгыльләнделәр.* Т.Миңнуллин

**СПЕЛЕОЛОГ** *и. гр.* Спелеология белгече. *Ә хәзер куркуымны җиңәргә өйрәндем: спелеологлар төркеменә язылдым.* Ватаным Татарстан

**СПЕЛЕОЛОГИЯ** *и. гр.* Мәгарәләрне, тау куышларын, аларның барлыкка килүен, үсешен, кулланылышын, эчке климатын һ.б.ш. төрле яклап өйрәнә торган фән тармагы

**СПЕ́РМА** *и. гр.* Ир кеше һәм иркәк хайванның җенес органы бүлеп чыгара торган, җенес күзәнәкләреннән һәм орлык сыекчасыннан гыйбарәт матдә; мәни. *Сигезаякның спермасы сигез капшавычының берсендә була.* Кызыклы физиология. *Уылдык чәчү чорында ата бака ана баканың аркасында утыра. Бу бик уңайлы, чәчелгән уылдыкка шундук сперма сибелә.* Зоология

**СПЕРМАТОГЕНЕЗ** *и. гр. мед.* Ата җенес күзәнәгенең үсүе һәм өлгерүе

**СПЕРМАТОЗО́ИД** *и. гр. физиол.* Аерым җенесле организмнарда ата җенес күзәнәге, аталык орлыгы. *Шунысы кызыклы: сперматозоидлар тулган капшавыч, сигезаякның гәүдәсеннән аерылып, мөстәкыйль рәвештә дә яши ала.* Кызыклы физиология

**СПЕ́РМИЙ** *и. гр. к.* **сперматозоид**

**СПЕЦИАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Хуҗалыкны бер генә тармак буенча эш алып барырлык итеп үзгәртеп кору; махсуслаштыру. *Бүгенге көндә метрология үзәге составында ике специальләштерелгән махсус лаборатория эшли ---.* Бөгелмә авазы. *Авыл хуҗалыгы производствосын специальләштерү. Специальләштерелгән хуҗалыкара предприятиеләр төзү*

**Специальләштерә бару** Специальләштерү эшен эзлекле дәвам итү

**Специальләштерә башлау** Специальләштерергә керешү

**Специальләштерә төшү** Тагы да специальләштерү

**Специальләштереп бетерү** Специальләштерүне тәмамлау, тулысынча специальләштерү

**СПЕЦИАЛЬЛӘШҮ** *ф.* Хуҗалык, белгечлек һәм фәннең бер генә тармагын яки тар өлкәсен сайлап алып, шул юнәлеш белән чикләнү, шуның белән генә шөгыльләнү; махсуслашу. *Латышларның аерым телләр буенча специальләшкән, тәҗрибәле кадрлары да шактый.* Р.Фәйзуллин. *Ләкин мин анда укыганда да шәрык телләре буенча специальләштем, фарсы телен өйрәндем.* Р.Вәлиев

**Специальләшә бару** Специальләшүне дәвам итү

**Специальләшеп бетү** Тәмам, тулысынча специальләшү

**Специальләшеп килү** Акрынлап специальләшү

**Специальләшеп җитү** *к.* **специальләшеп бетү**

**СПЕЦИ́ФИК** *с. кит.* Берәр тар өлкәгә генә караган, үзенә генә хас булган, үзенчәлекле. --- *органик булмаган теория буенча теләсә кайсы җирдән нефть, газ чыгарга тиеш. Ә органик генезис буенча исә бары аерым специфик урыннарда гына нефть, газ ятмалары була.* Х.Камалов. *Һәр тармакның анда эшләүче профессионаллар гына аңлый торган специфик проблемалары бар.* Ватаным Татарстан

**СПЕЦИ́ФИКА** *и. лат. кит.* Аерым предметка, эш-гамәлгә хас билгеләр, үзенчәлекләр җыелмасы; нинди дә булса бер үзенчәлекне чагылдырган аерымлык. *Фәнни хезмәтнең спецификасы. Авыл тормышының спецификасы*

**СПЕЦИ́ФИКАЛЫ** *с.* Үзенчәлекле, билгеле спецификасы булган

**СПЕЦО́ВКА** *и. рус* Гадәттә җитештерү тармагында эшләүчеләр кия торган махсус кием, эш киеме. *Өстеңдәге киемеңне бер дә алыштыра белмисең. Махсус яздырып алган спецовка шикелле.* Э.Яһудин. *Аннан соң Бабай, бик җаваплы эш эшләгәндәй, һәрберсен аерым чакырып алып, исемлеккә кул куйдыртып, спецовка таратты ---.* К.Кара

**СПИДО́МЕТР** *и. ингл. махс.* Транспорт чараларында йөреш тизлеген һәм үтелгән юлны күрсәтә торган прибор. *Сызраньга җитәрәк, спидометр эшли башлады. Бу – безнең өчен куаныч: Ходай безне ташламый, ярдәм итә!* З.Зәйнуллин

**СПИ́КЕР** *и. ингл.* 1) *сәяси* Парламентның яки аның аерым бер палатасының рәисе. *Сорауларга җавап биреп, спикер шулай ук соңгы араларда Россиянең сәяси тормышында бара торган үзгәрешләр, яңалыклар турында да үз фикерен әйтте.* Г.Камалова

2) Гомумән утырыш, тапшыру һ.б.ш.ны алып баручы; чыгыш ясаучы, оратор. *Аида Җиһаншина әлеге форумнан «Иң яхшы спикер» исемен алып кайта.* Э.Һади

3) *спорт* Бокс ярышларында судьяларның карарын игълан итүче кеше

4) *тех.* Электрон җайланмаларда, компьютерларда була торган тавыш яңгыраткыч җайланма, динамик

**СПИ́ННИНГ** *и. ингл.* Җеп чорнау өчен кәтүгә булган, җеп очына вак балыкка охшаш ялтыравык алдавыч

тагылган, озын саплы балыкчы әсбабы. *Спиннинг ул, малайлар. Чуртанише эре балык тота торган нәмәрсә.* А.Тимергалин. *Лесниковның аягында озын итек, буыннары ялгана торган спиннинг тагылган җебен беләгенә элгән, җылырак киенгән.* С.Шәрипов

**СПИРАЛЬ** *и. гр.* **1.** 1) *мат.* Бер нокта яки күчәр тирәли әйләнеп, зурая яки кечерәя барган саен йомык булмаган әйләнәләр хасил итә торган кәкре сызык. *Тарихта үсеш спираль рәвешле бара, диләр.* Р.Фәйзуллин. *Безнең Галактикабыз үзе дә, чиксез зур аралыклар аша узып, Галәмнең гаҗәеп зур спирале буенча хәрәкәт итә.* С.Шәмси

2) Шундый кәкре формасындагы винтсыман сызык // Шул сызык рәвешле бөтерелгән, уралган предмет. *Йомычка спирале*

3) Винтсыман уралма формасындагы тимерчыбык, пружина. *Электр плитәсе спирале. Лампочканың спирале яну*

**2.** *с. мәгъ.* Спираль (*1 мәгъ.*) формалы, бормалы. *Алексей толыпны ачып ташлады һәм янында зур, спираль мөгезле олы меринос тәкәсе басып торганын күрде ---.* Х.Камалов

**СПИРЕ́Я** *и. гр. бот.* Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан чатыр яки чуксыман оешма чәчәкле, яфрак коя торган декоратив куак. *Розачәчәклеләр семьялыгында декоратив үсемлекләр дә бар, мәсәлән, дүләнә һәм спирея шундый үсемлекләрдән санала.* Л.Мәүлүдова

**СПИРИТИЗМ** *и. лат.* 1) XIX йөз уртасында француз галиме Аллан Кардек тарафыннан нигез салынган, кешелек реинкарнацияләр юлы белән рухи үсешкә ирешә ала, дип раслаган динифәлсәфи тәгълимат

2) Үлгән кешеләрнең рухлары белән бәйләнешкә керү мөмкин, дигән мистик караш һәм шуны башкару гамәле. *Спиритизм латинчадан «җан», «рух» дип тәрҗемә ителә. Ул – үлгән кешеләрнең рухы белән элемтәгә керү ысулы.* Гаилә һәм мәктәп. *Спиритизм белән мавыгу*

**СПИРИТУАЛИЗМ** *и. лат.* Фәлсәфәдә чынбарлыкның беренчел нигезе итеп материягә, кеше аңына бәйсез булган «җан», «рух»ны күрсәткән идеалистик тәгълимат

**СПИРИТУАЛИСТ** *и. лат.* Спиритуализм тарафдары

**СПИРО́МЕТР** *лат.-гр. махс.* Сулыш белән чыккан һаваны үлчәп, үпкәнең сыйдырышын билгели торган прибор. *Спирометр аппараты ярдәмендә үпкәнең ничек эшләвен ачыкладылар.* Ватаным Татарстан

**СПИРТ** *и. ингл. хим.* 1) Шикәрле, крахмаллы матдәләрне махсус куу юлы белән алынган алкогольгә бай сыекча. *Өч җирдә зур имениеләре, ике спирт заводы һәм зур ат заводы аның милкендә иде.* Ш.Камал. *Камырдагы чүпрә шикәрне спиртка һәм углекислый газга тарката.* Гөмбәләр, лишайниклар

2) Составында гидроксил төркеме (-ОН) булган органик кушылма (мәс., глицерин, фенол). *Шешәнең бөкесен ачып иснәде дә иснәде. Нашатырлы спирт исе таралды.* Х.Камалов. *Ике атомлы феноллар үсемлекләрдә, башлыча спиртлар, кислоталар, эфирлар хәлендә һәм шулай ук ирекле хәлдә очрыйлар.* Агулы үсемлекләр

**СПИРТЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **спиртлау**

2) Спирт салыну; спирт сөртелү, спирт сеңдерелү

3) *күч.* Спиртлы эчемлекләрне күп куллану. *Сиңа да нокта буласы иде, спиртланмасаң, дим, җелегеңә салкын үтеп, дим.* Н.Гыйматдинова. *Без бит айнымыйча эчмибез. Хе-хе-хе. Кәнишне, сиңа ләззәт. Спиртлангач.* Г.Каюмов

**Спиртланып бетү** Нык спиртлану. *– Кайнаган су да ярый, – ди пәһлеван, – бу типның бөтен организмы спиртланып беткән, бер микроб та якын килерлек түгел!* Г.Афзал

**СПИРТЛА́У** *ф.* 1) Спирт (*1 мәгъ.*) катнаштыру, спирт кушу. *Гранат согын спиртлау*

2) Бозылмый саклансын өчен, спирт белән эшкәртү яки спиртка салу. *Анатомик музей экспонатларын спиртлау*

**Спиртлап алу** Тиз генә спиртлау

**Спиртлап бетерү** Барысын да спиртлау

**Спиртлап кую** Алдан спиртлау

**Спиртлап тору** Әле, күз алдында спиртлау; даими спиртлау

**Спиртлап чыгу** Баштан ахырга кадәр, рәттән спиртлау

**Спиртлый башлау** Спиртларга керешү

**СПИРТЛЫ** *с.* 1) Составында спирт булган, спирт кушылган. *Склад мөдире спиртлы эчемлекләрне бик ярата һәм ярдәмчел урынбасарына чиксез ышана иде.* Ә.Мушинский

2) Спирт тутырылган; спирт белән чылатылган яки спирт сеңдерелгән. *Ася аркадагы яраларны спиртлы тампон белән чистартты, аларга яра пластыре ябыштырып чыкты.* Х.Камалов. *Соломон Моисеевич авыру кешенең тәненә тигән кулларын, резина чүкеч, энә ише нәрсәләрен спиртлы мамык белән сөртеп куйды.* Н.Фәттах

**СПИРТО́ВКА** *и. рус махс.* Спирт яндырып эшли торган җайланма; спирт лампасы. *Мостафа нигәдер, күрәчәгенә каршымы, аның кабинетына керде, Хәлимә янына килде һәм спиртовка кабызып торган кызның йомшак җилкәсенә кулын куйды.* М.Мәһдиев. *Дистиллятор – зур колба, астына спиртовка куеп, шуның эчендә су кайнатасың.* М.Маликова

**СПО́НСОР** *и. ингл.* 1) Үзенең эшчәнлеген яки товарын рекламалау бәрабәренә бирәүгә финанс ярдәме күрсәтүче физик яки юридик зат. *Спонсорлар чыгарган китапка гонорар түләнми икән, гонорар урынына китапларымны бирделәр.* Ф.Яруллин. *Спонсор түләүсез ярдәм күрсәткән оешмага карата юридик хокукларга ия булмый.* Татарстан

2) *сөйл.* Гомумән бирәүгә матди, акчалата ярдәм күрсәтүче кеше, иганәче

**СПОНСОРЛЫК** *и.* Спонсор гамәле, спонсор эшчәнлеге. – --- *Безнең мәҗлескә бераз спонсорлык ярдәме кирәк булыр, дигәние [Рамил абый], – диде Мисхәт, аяк бармакларына чаклы кызарып.* Т.Галиуллин. *Спонсорлык буенча мин дә калышмыйм, Казанда яшәүче хирург Якубның юбилеена гына йөз мең сум тоттым.* С.Зартдинов

**СПО́РА** *и. гр. биол.* 1) Гөмбә, лишайник, сүүсем кебек түбән төзелешле, мүк, абага кебек югары төзелешле

үсемлекләрнең микроскопик яралгы күзәнәкләре. *Споралар су агымы, суалчаннар, бөҗәкләр һәм шулай ук кеше эшчәнлеге ярдәмендә туфракта саклана.* Л.Мәүлүдова. *Кисәү гөмбәсенең споралары*

2) Кайбер иң гади төзелешле хайван һәм бактерияләрнең бер яки күп күзәнәкле үрчү органы. *Күрән спора бөреләреннән торган беркүзәнәкле җенессез үрчү органнары җыелмасы (соруслар), ике рәт булып, яфрак сеңерчәләренең аскы ягына урнашканнар.* Агулы үсемлекләр. *Плаунсыманнарның спора өлгертү башаклары*

**СПОРА́НГИЙ** *и. гр. бот.* Түбән төзелешле үсемлекләрдә – беркүзәнәкле, югары төзелешлеләрдә күпкүзәнәкле җенессез үрчү органы, споралар оялыгы. *Спорангий ясала башлаудан алып өлгергән споралар коелганга кадәр берничә ай яки хәтта ел үтә.* Биология

**СПОРТ** *и. ингл.* 1) Физик культураның организмны ныгытуга юнәлтелгән физик күнегүләр ясаудан гыйбарәт өлеше. *Аның өстендә чип-чиста, өр-яңа спорт киеме, Камилнең әле аны күргәне дә юк иде.* Ф.Бәйрәмова

2) Ярышларда шундый күнегүләр ясау. *Акча күп булмаса, дөнья хәтле акча түгеп, ничәмә-ничә спорт командасын тотмас идек.* Т.Миңнуллин. *Кыз спорт белән нык шөгыльләнде, үзендә физик көч барын да белә, ихтыяры һәм рухи ныклыгы җитәрлек икәнен дә яхшы тоя иде.* Р.Кәрами

3) Шундый күнегү комплекслары, төрләре буенча ярышлар һәм күнекмәләр оештыру һәм үткәрү системасы. *Миңа шәһәр спорт комитетыннан безнең йорт идарәсе каршында яхшы эзерлекле, тимер дисциплиналы футбол командасы оештыруны йөкләделәр.* Т.Гыйззәт. *Баш редакторыбыз Асия Хәсәнова миңа, мәсәлән, промышленность, спорт, төзелеш, кул эшләре, партия һәм сәнгать бүлекләрен тапшырды.* К.Тимбикова

4) *күч.* Бик нык мавыгып, күңел биреп шөгыльләнгән нәрсә. *Марка җыю аның өчен бер спортка әверелде инде*

**СПОРТ-** *ингл.* Кушма сүзләрнең «спорт белән бәйле» мәгънәсен белдергән беренче компоненты (мәс., *спортинвентарь, спорттовар*)

**СПОРТЗАЛ** *и. рус* Спорт күнегүләре ясау, ярышлар үткәрү һ.б.ш. өчен махсус зал, бүлмә. *Дәресләр беткәч тә кайтып китә алмадым, драмтүгәрәк, спортзал, бетмәс-төкәнмәс хәзинәсе белән китапханә.* М.Мәһдиев. *Эшне башлап җибәргәндә бик җиңел булмый, чөнки спортзал бик бәләкәй, инвентарь юк.* Р.Корбан

**СПОРТКАР** *и. ингл.* Җиңел автомобильнең спорт моделе

**СПОРТЧЫ** *и.* Спорт белән шөгыльләнүче кеше. *Спортчыдан аермалы буларак, шагыйрьнең бер өстенлеге бар: спортчы – физик көчкә, ә шагыйрь акылга таяна.* Ф.Яруллин. *Әмир, допинг алган спортчы төсле кыюланып, һөҗүмгә күчте.* Т.Галиуллин

**СПРА́ВКА** *и. рус* Берәр фактны раслый яки берәр нәрсәгә хокук бирә торган эш кәгазе; документ, язма белешмә. *Колхоз председателе, үлсәң дә, паспорт алырга справка бирмәячәк.* Ф.Яруллин

**СПРЕЙ** *и. ингл.* 1) Сыекчаны билгеле юнәлештә пошкырту, сиптерү өчен махсус җайланма

2) Сиптергече булган баллонга тутырылган берәр төрле косметика чарасы, көнкүреш химиясе, буяу һ.б.ш. *Һаваны сафландыру чаралары спрей, порошок, төймә, электр системалары кебек формаларда булырга мөмкин.* Гаилә һәм мәктәп. *Бит-кулларга әлеге хәшәрәтләргә каршы крем сөртмичә яки спрей-мазар сиптермичә, урманнарга, хәтта посадка-болыннарга да якын килерлек түгел.* Татарстан яшьләре

**СПРИНТ** *и. ингл. спорт* Кыска дистанциядә тизлеккә йөгерү, йөзү, тимераякта яки велосипедта узышу кебек спорт ярышы. *Шул ук 1968 елны Мехикода үткән Олимпия уеннарында АКШның ике кара тәнле җиңел атлетикачысы Томми Смит белән Джон Карлос спринт буенча алтын һәм бронза медальләр яулады.* Ә.Мушинский. *Дөнья кубогы ярышларында байтак медальләр яулаган Иван Черезов, Евгений Устюгов, Максим Чудов спринт узышында үзләрен күрсәтә алмадылар.* Татарстан яшьләре

**СПРИ́НТЕР** *и. ингл.* Спринт ярышларында катнашучы спортчы

**СПРУТ** *и. ингл.* Сигезаяк яки кальмар кебек башаяклыларның эре төрләренең гомуми атамасы. --- *кинәт кенә капиталистик мөнәсәбәтләр үсеп, куәтләнеп китә. Билгеле инде, бу мөнәсәбәтләр, төрле якка сузылган спрут кулларыдай, башкортларны да үз «кочагына» тартып ала.* Олы юл өсте

**СПУ́ТНИК** *и. рус* Берәр күк җисеме тирәсендәге орбитага җибәрелә торган космик аппарат, ясалма иярчен. *Әле менә шушы көннәрдә генә ясалма беренче спутник җибәрделәр.* М.Мәһдиев. *Күктә исәпсез-сансыз спутниклар оча, адәми зат Айдагы агрегатлар белән идарә итәргә өйрәнде.* Г.Бәширов

**СРОК** *и. рус* 1) Берәр эш-гамәл үтәлү өчен бирелгән билгеле вакыт аралыгы; мөддәт. *[Фаттах:] Минемчә, Мансур иң азында биш ел сугышырга җыена, шул срокка җитәрлек запас җыя.* Ш.Усманов. *Әгәр мин сезгә ике көн срок бирсәм, сез аны биш көнгә сузачаксыз. Шулай бит?* А.Хәсәнов

2) Берәр эшнең башланырга яки башкарылып бетәргә тиешле датасы, елы, ае, көне кебек төгәл вакыты. *Срогы җиткәч, бирәчәкне түләргә кирәк. Срогында түләмәсәң, вексельнең «протест» дигән бәлагә эләгүе бар.* Ш.Мөхәммәдев. *Бездә яшәүче барлык кошлар да яз көне үрчиләр, ләкин төрле срокларда.* Биология

3) *сөйл.* Хөкем ителгән кешегә билгеләнгән җәза зурлыгы, иректән мәхрүм ителү вакыты. *Ике айдан соң суд булды, һәм «пленный» Сәмигулланың малайларына сроклар бирделәр.* М.Мәһдиев. *Гали Рәхимне – срогын тутырып кайткан «зек»ны – Гайшәнең әнисе үзләренә кабул итә, шунда яшәтә.* Мәдәни җомга

**СРОКЛЫ** *с.* 1) Срогы алдан билгеләнгән, срогы билгеле булган. *Кронштадтагы кыска сроклы өйрәтү отрядына килеп кергәндә, Рушадка унсигез яшь тулып ике ай гына киткән иде.* М.Мәһдиев. *Гөлчирә сугыш башланган елның көзендә шәфкать туташлары*

*әзерли торган кыска сроклы курста укыган.* Г.Галиев

2) Билгеле бер срокта эшләргә яки эшләнергә тиешле. *Бу үзе дә күп нәрсә сөйли: сроклы хезмәттә сержантларның бик сирәге старшинага кадәр үсә, моны армиядә булганнар яхшы белә.* Туган як. *Түмән драма театры француз актёры Жерар Депардьены үзенә эшкә чакырырга планлаштырып, аңа сроклы хезмәт килешүе, шәһәр үзгендә фатир бирергә әзерлеген белдерә.* Яңарыш

**ССУ́ДА** *и. рус махс.* Оешмага яки аерым кешегә кире кайтару шарты белән бирелә торган акча. *Оргнабор рекламаларында шундый сүзләр бар иде: баргач та һәр гаилә торак урыны белән тәэмин ителә, --- сыер алу өчен дәүләт ссуда бирә.* М.Мәһдиев. *Язын, нәкъ юл өзекләрендә, колхозга хәбәр килеп төшә: ссудага чәчүлек орлык бирелә, заготзернодан килеп алыгыз.* Р.Төхфәтуллин

**СТАБИЛИЗА́ТОР** *и. рус махс.* 1) Автоматикада, очкыч һ.б.ш. аппаратларда үзәкнең даими торышын саклау, тотрыклык бирү җайланмасы, тотрыкландыргыч. *Койрыкта – стабилизатор, очканда минага дөрес юнәлеш бирүче.* С.Поварисов. *Стабилизатор канатларын калибрлап өлгертә алмау аңарда шушы эшне тизләтү өчен берәр нәрсә уйлап табу теләген уятты.* Канатлы малайлар

2) Электр тогының даимилеген саклауга хезмәт итә торган җайланма. *Ешлык стабилизаторы. Көчәнеш стабилизаторы. Электроник стабилизатор. Электр агымы стабилизаторы*

3) Сәнәгать ысулы белән әзерләнгән азык-төлеккә әчү, кату һ.б.ш. кебек процессларны булдырмыйча, ризыкның саклану срогын арттыру өчен кушыла торган матдәләр; тотрыклагыч

**СТАБИЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат. кит. к.* **стабильләштерү**

**СТАБИЛЬ** *с.* **1.** Тотрыклы, ныклы, даими. *Безнең үзебезнең республикада чагыштырмача стабиль тормыш: экономик яктан да, сәяси яктан да.* Р.Миңнуллин. *Иҗат кешесенә, төнге режим белән эшләгәч, гастрольләрдә күп йөргәч, стабиль эш табу читен.* Л.Йосыпова

**2.** *рәв. мәгъ.* Тотрыклы, ышанычлы, эзлекле рәвештә; даимән. --- *«коммунизм»ның төзелеп бетәргә тиешле чоры бу. 30 елның егермеләбендә Брежнев стабиль идарә иткән чор.* Р.Фәйзуллин

**СТАБИЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф. кит.* Стабиль хәлгә китерү, тотрыклы итү, шул хәлдә ныгыту. *Экономиканы стабильләштерү. Стандартларның нормаларын стабильләштерү. Ешлыкны стабильләштерү*

**Стабильләштерә бару** Торган саен ныграк стабильләштерү

**Стабильләштерә башлау** Стабильләштерергә керешү

**Стабильләштерә төшү** Тагы бераз стабильләштерү

**Стабильләштереп бару** Эзлекле рәвештә бер-бер артлы стабильләштерү

**Стабильләштереп җиткерү** Ахыргача стабильләштерү

**СТАБИЛЬЛӘШҮ** *ф. кит.* Стабиль, тотрыклы хәлгә килү, тотрыклыга әйләнү; шундый хәлдә ныгу. *Кайсысы гына экранга чыгып утырмасын, бер үк сүзне туглый: рубль ныгыды, диләр, экономика стабильләште, доллар пүчтәкләнә башлады, акчаны рубльләрдә саклау отышлы, диләр.* Ф.Баттал

**Стабильләшә бару** Эзлекле рәвештә стабильләшү

**Стабильләшә башлау** Стабильләшүгә табан үзгәрү

**Стабильләшә төшү** Тагын да стабиль хәлгә килү; бераз стабильләшү

**Стабильләшеп алу** Аз гына вакытка стабильләшеп, кире үз хәленә кайту

**Стабильләшеп калу** Нининдидер сәбәптән соң стабильләшү һәм шул хәлен саклау

**Стабильләшеп килү** Акрынлап, азазлап стабильләшү

**Стабильләшеп китү** Билгеле моменттан алып стабильләшү

**Стабильләшеп бетү** Тулысынча стабильләшү

**Стабильләшеп җитү** *к.* **стабильләшеп бетү**

**СТАБИЛЬЛЕК** *и. кит.* Стабиль булу хәле, стабильләшү күренеше, стабиль булу дәрәҗәсе, тотрыклылык. *Ә җәйге эсседә сарыклар ничек чыдый дип уйлыйсыз? Читтән килгән нәселнең бик күбесе чыдый алмый. Аларда генетик стабильлек юк.* М.Мәһдиев. *Тикшеренүчеләр фикеренчә, Бөекбритания кешеләрен берләштерә торган милли характер сыйфатлары түбәндәгеләр: стабильлек һәм даимилек, сабырлык, башкаларның эшләренә катышмау, аралашмаучанлык, индивидуальлек, хисләрен йөгәндә тоту, тәвәккәллек.* А.Низаметдинова

**СТА́ВКА** I *и. рус хәрби* 1) Гаскәр башлыгы яки аның штабы урнашкан урын. *Бату һәм Бәркә заманнарыннан алып, Алтын Урда ханнарының ставкасы, күчмә урын буларак, я далада, я шәһәрләрдә урнашкан.* А.Халиков. *А.Фёдоров-Давыдов «урда» сүзенең «күчмә ставка», «каанның, ханның яки олысның башка хәкименең күчмә резиденциясе» дигән мәгънәләрен китерә.* Мирас

2) Сугыш вакытында: иң югары командование органы. *Ставка 22–23 майда Генштаб һәм фронт командующийлары, хәрби совет әгъзалары катнашында «Багратион» буенча зур киңәшмә уздыра.* З.Зәйнуллин. *Шулай бервакыт фронттан – сугышның алгы сызыгыннан әйләнеп кайткан ставка вәкиле Сталин каршында --- зарлана башлый.* Р.Низамиев

**СТА́ВКА** II *и. рус* 1) Хезмәт хакының билгеле вакытта башкарылган конкрет эш өчен бирелә торган тотрыклы күләме. *«Миңа нинди ставка буенча түлисез?», «Соңгы графа буенча минем кулга күпме акча керәчәк?», «Күпме тотыла?» кебек сораулар белән ул директорның башын катырды.* М.Мәһдиев. *Конторда эшләмәүче ике инженер ярты ставка акча алып яталар: Сибгатуллин, Тимәшев.* Х.Камалов

2) *фин.* Кредит, заём һ.б.ш. эшләрдә процентларның рәсми билгеләнгән күләме. *Бервакыт кредитлар буенча киметелгән ставкаларны бездә муниципаль компенсацияләр хисабына бары тик бер банк финанслый иде.* Татарстан. *Минималь айлык тариф ставкасы. Кабаттан финанслау ставкасы*

**СТАВРИ́ДА** *и. гр. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан ставридачалар семьялыгына караган балык төрләренең гомуми атамасы

**СТАВРИ́ДАЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан өерләре белән яшәүче, күп төрләре промысел объекты булган диңгез балыклары семьялыгы

**СТАДИОН** *и. гр.* 1) Спорт күнегүләре ясау, ярышлар үткәрү өчен махсус мәйданчыклары, зур кыры, ярдәмче биналары һәм тамашачылар утыру өчен урыннары булган комплекслы спорт корылмасы. *Мансур порт дамбасын узгач та, стадион буендагы дамбадан соң да кирегә борылмады.* Г.Әпсәләмов. *Бу кадәр халыкның бергә җыелганын, күрсәң дә, футбол яисә хоккей стадионнарында гына күрергә мөмкин безнең якларда.* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Спорт мәйданчыгы. *Хәзер исә клуб буш һәм караңгы, стадион чирәмендә кошлар гына чүпләнеп йөри.* М.Маликова

**СТА́ДИЯ** *и. гр.* Берәр нәрсәнең үсешендә сыйфаты белән аерылып торган, үзенчәлекле баскыч, этап, чор. *– Доктор Нигъмәтуллина токсикозның башлангыч стадиясендә диагноз кую методларын эзли, – диде Резеда Фәритовна, бик тә рәсми тавыш белән.* М.Маликова. *Күпчелек гөмбәләрдә сумка стадиясе язын, мәсәлән, кышлаган яфракларда башлана.* Агулы үсемлекләр

**СТА́ДИЯЛЕ** *с.* Билгеле стадияләрдән торган; берничә стадиядән гыйбарәт. *Әлеге законга нигезләнгән гореф-гадәтләр дүрт стадияле итеп каралган, һәм аларның барысын да башкару зарур.* Р.Сафин. *Стадияле үсеш теориясе*

**СТАЖ** *и. фр.* 1) Нинди дә булса өлкәдәге эшчәнлекнең, хезмәтнең дәвамлылыгы, берәр оешмада тору вакыты, нindидер эштә билгеле вазифада эшләгән еллар саны. *Хатын-кызга өч елы да ярыйсы стаж инде ул.* Э.Яһудин. *Гамәлдәге закон нигезендә, хатын-кыз бер бала тапса да, ун бала тапса да, аңа нибары өч кенә ел стаж языла.* Татарстан яшьләре

2) Эшкә урнашкан кешенең практик тәҗрибә туплау, белгечлекне үзләштерү өчен кирәк булган, шуңа карап шул эшкә яраву билгеләнә торган срок

**СТАЖЁР** *и. фр.* Сынау стажы үтүче

**СТАЖЁРЛЫК** *и.* Стажёр вазифасы, хезмәте. *Стажёрлыкта йөргән өчен, Маратка шактый гына хезмәт хакы язганнар.* Д.Гыйсметдин

**СТАЖИРО́ВКА** *и. рус* 1) Уку йортын тәмамлаган кешенең берәр учреждение, предприятие һ.б.ш.ның штатына алу алдыннан эштә сынау срогы узуы. *Консерваторияне тәмамлагач, яшь җырчы опера һәм балет театрында стажировка үтә.* Мәдәни җомга

2) Берәр белгечлекне үзләштерү, өйрәнү, күнекмә алу яки белемне күтәрү өчен производство, фәнни һ.б.ш. практика. *Концерттан соң Альбинаны Американың Хьюстон Гранд-Опера театрының арт-директоры үзләренә стажировкага чакыра.* М.Галиуллина. *Президент исеменнән яшь артистларга чит илләрдә стажировка үтәргә мөмкинлек бирә торган сертификат тапшырылды.* Татарстан

**СТАЖЛЫ** *с.* Билгеле стажга ия булган; стажы күп булган, эш стажы зур булган. *Мәдрәсәнең иң зур стажлы шәкертләре исеменнән сезне тәбрикләргә кердем.* С.Кудаш. *Бәлки, Мөнирҗанның стажлы зек булуы да роль уйнагандыр.* Н.Әхмәдиев

**СТА́ЙЕР** *и. ингл.* Ерак аралы узыш ярышларында катнаша торган спортчы. *Йөгерешче стайер. Велосипедчы стайер*

**СТАКАН** *и.* 1) Чәй, су эчү өчен кулланыла торган, цилиндр формалы, сапсыз, пыяла, бәллүр һ.б.ш. материалдан эшләнгән савыт; тустаган. *Даутов стаканнан бер йотым су эчте, тынып торды.* М.Мәһдиев. *Аннары аңа чәй эчерделәр. Няня калак белән авызына салып торды. Әнвәрнең стакан тотарлык та егәре калмаган иде.* Х.Камалов

2) Шундый савытка салынган эчемлек; шул эчемлекнең яки башка нәрсәнең микъдары. *Иртән сыек кына бер стакан чәй эчерткәч, тагын сорау алырга чакырдылар.* А.Гыйләҗев. *Кияү әле генә бер стакан каплап куйган мулланың шома гына борчак сибүенә хәйран калып утыра.* И.Сираҗи

3) *тех.* Төрле механизмнарның цилиндр формасындагы җайланмасының, деталенең атамасы. *Савучы кыз алда торган беренче сыерлар янына килде һәм шунда ук, баядан бирле савылган сыердагы стаканнарны алып, Красотканың җиленәнә кидереп куйды.* М.Хәсәнов

4) Артиллерия снарядының тышчасы, корпусы

**СТАКАНЛАП** *рәв.* 1) Стакан белән үлчәп, стаканнарга бүлеп. *Авылның бөтен тормышы урман белән. Утын, печән – шуннан. Җиләк, карлыган – шуннан. Җыясың, станциягә алып барып, стаканлап сатасың – акча була.* М.Мәһдиев. *Җәй көне ул чикләвек җыеп, стаканлап сатып утыра.* Ф.Садриев

2) Стакан-стакан, күпләп; стакан тутырып. *Ашамыйча-нитмичә бер-бер артлы стаканлап эчү үзенекен итте: Борһанга бераз җан кергәндәй булды.* М.Хәсәнов. *Агайның теше сызлый. Басылмасмы дип, стаканлап аракы чөмерә.* Ш.Галиев

**СТАКАНЛА́У** *ф. сөйл.* Стакан белән үлчәү. *Чикләвекне стаканлау. Көнбагышны стаканлау. Ярманы стаканлау*

**Стаканлап тору** Әле, хәзерге вакытта стаканлау

**Стаканлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр стаканлау

**СТАКАНЛЫ** *с.* 1) Стакан эчендәге, шуңа салынган. *Һәм тавыш җепселләре коргаксыса йотып куярга диелгән стаканлы суны тотып, [Сөмбелә] егеткә таба атлады.* К.Кәримов. *Стаканлы каймак*

2) Стакан белән үлчәнгән; аз. *Стаканлы чикләвек күпкә җитмәс*

**СТАЛАГМИТ** *и. гр.* Тау куышлыкларында өстән тамган минераллы су катып калып, мәгарә төбендә хасил булган сөңге, конус, багана формасындагы минераль ясалма. *Сталагмитлар мәгарә төбенә тамган известьле су тамчыларыннан барлыкка киләләр, еш кына колонналар хасил итәләр.* Кызыклы география

**СТАЛАГМИТЛЫ** *с.* Сталагмитлары булган. *Сталагмитлы мәгарә*

**СТАЛАКТИТ** *и. гр.* Тау куышлыкларында югарыдан сарыккан минераллы су катып, куышлык түшәмендә хасил булган, өстән асылынып торган сөңге рәвешендәге утырма. *Монысы – җир астындагы сталактит мәгарәсе.* М.Мәһдиев

**СТАЛАКТИТЛЫ** *с.* Сталактитлары булган. *Сталактитлы рудник*

**СТАЛИНИ́ЗМ** *и. рус к.* **сталинчылык**. *Татарлар, сталинизм мәңгегә килде, һәм ул мәңге җимерелмәс дип, бик каты ялгыштылар.* Р.Батулла. *Ә сталинизм безне әнә никадәр артка алып ыргыткан!* М.Вәлиев

**СТАЛИНЧЫЛЫК** *и. кит.* И.В. Сталин дәүләт һәм хөкүмәт белән идарә иткән чорда формалашкан тоталитар идарә итү стиле. *Сталинчылык проблемасы безнең җәмгыять өчен актуаль һәм әрнүле булып кала бирә.* Татарстан

**СТАМЕ́СКА** *и. нем. сөйл.* Столяр һәм балта эшләрендә агачта кулдан тирән булмаган уемнар ясау өчен кулланыла торган эш коралы; яссы өтерге; уймыр, аталгы. *Ярымтүгәрәк стамеска*

**СТАН** I *и. рус* 1) Басым көче белән эре металл эшләнмәләр ясый торган машина яки машиналар системасы. *Кайнар хәлдә прокатлау станнарының подшипникларын --- пластмассадан ясау файдалырак булуы 1932 елда ук исбат ителгән иде.* Г.Камай

2) Хуҗалыкта төрле эш башкару өчен корылган, гадәттә агачтан эшләнгән җайланма яки кечерәк корылма. *Берничә урында озын терәкле станнарга салып такта яралар.* К.Нәҗми. *Безнең өйдә агач станында юкәдән кырып ясалган җиде бадьян – ипи савыты бар.* М.Мәһдиев. *Сабирҗан агай тәгәрмәч суга торган станга утырды да ашыкмый гына күн алъяпкычын салды.* М.Шәрифуллин

3) Нинди дә булса механизм, авыр эш коралы кебекнең нигезе, терәге

**СТАН** II *и. рус* 1) Хәрбиләрнең вакытлы тукталу урыны, лагерь, урда. *Хан станы белән Нарым арасында кыргыз халкы яши, монда кар аз төшә; җәйләрен алар Кабарчык елгасы белән Нарым арасында күчмәлек итәләр.* М.Галиев

2) Кырчылык, балыкчылык һ.б.ш. сезонлы эшләрдә бригадалар вакытлыча урнашкан урын, шуларның торак урыны. *Шул ук стан күренеше. Айсыз җәйге төн. Барысы да йоклыйлар. Кибән артында ике кешенең пышылдап кына сөйләшүләре ишетелә.* А.Алиш. *Яшьләр кайсы җәйләүдә, кайсы печән чабарга киткән, кайсыберләре кыр станнарында.* Н.Дәүли

3) Почта станциясе. *Почта станының тар-мар ителүе бөтен Исет трактын эштән чыгара.* С.Алишев

4) *тар.* Россиядә 1917 елга кадәр өяznең административ бүленеш берәмлеге

**-СТАН** III *фар.* Кушма сүзләрнең «ил, дәүләт» яки «нәрсәнеңдер бик күп булган урыны» мәгънәсен белдерә торган компоненты (мәс., *Татарстан, Башкортстан, Һиндстан; каберстан, гөлстан*)

**СТАНДАРТ** *и. ингл.* **1.** 1) Эшләнмәләрнең, товарларның, хезмәт күрсәтүнең тиешле сыйфат характеристикаларын билгели торган документ. --- *Заводтан эре ташлы бетон җибәрәләр. Безнең стандарт буенча, вак ташлы булырга тиеш.* А.Гыйләҗев. *Татарстан мәгариф һәм фән министры карары белән федераль стандартлар нигезендә яңа әдәбият дәреслеге әзерләнә.* Мәдәни җомга

2) Бериш нәрсәләр өчен норма итеп алынган үрнәк, өлге, эталон. *Авырлык стандарты. Халыкара стандартлар*

3) *күч.* Бер үк төрле нәрсә, әзер үрнәк, шаблон. --- *берәүне бүтәннән аерып куя алырлык сыйфатлар да булырга тиеш ләбаса! Адәм баласы кирпеч калыбыннан төшкән стандарт түгел!* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Стандартка (*1 мәгъ.*) туры килә торган, билгеле өлге белән эшләнгән. *Стандарт зурлыктагы детальләр. Стандарт зурлыктагы тәрәзә өлгеләре*

2) Кабул ителгән, гадәти булган, иң еш очрый торган. *Парлы сүзләр ясалганда, бу «иске» сүзләрнең мөстәкыйль кулланылышында күзәтелми торган, стандарт булмаган күренешләр дә очрый.* М.Нигъмәтуллов. *Безнең стандарт лифтларга биш кеше сыя, дип язалар.* Л.Әбүдәрова

3) Башкалардан аерылмаган, бердәй булган, бертөсле. *Килгән көнне үк инде ул шифер түбәле, һәйбәт стандарт ферма биналарын күрде.* М.Хәсәнов. *--- уку йортларында стандарт кешеләр һәм стандарт халыклар тәрбияләнергә тиеш түгел.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Гадәтләнгән рәвешле, бертөрле, бер калып, бер ысул белән бара торган. *Стандарт фикерләү, гавами психология һәлакәткә дә китерергә мөмкин.* Х.Миңнегулов. *Шуңа күрәдер, бәлки, безнең яшьләрнең күбесе стандарт фикерле һәм шаблон карашлы.* М.Вәлиев

5) *күч.* Еш кабатлана торган, туйдырып бетергән, шаблон, штамп булган. *Баштарак ул хатларга «мәсьәлә өйрәнелә» дигән стандарт кына җаваплар да килә иде.* М.Вәлиев. *Нәтиҗәдә, сәхнәдә төссез, фәлсәфи асылы югалган, мең дә бер тапкыр кабатланган, берсе берсеннән аерылмаган стандарт спектакльләр куела.* Д.Гыймранова

**3.** *рәв. мәгъ.* Гадәтләнгән рәвештә, шаблон буенча, бертөрле, яңалыксыз. --- *әнә карагыз, укыгыз: бездә стандарт фикерләүчеләр дә, стандарт форма белән генә яшәүчеләр дә юк.* И.Гази

**СТАНДАРТЛАШТЫРУ** I *ф.* 1) Билгеле стандартка туры китерү, яраклаштыру, әзер өлгегә, әзер калыпка салу. *Аларны да стандартлаштырыйкмы?* Татарстан яшьләре

2) Бердәйләштерү

**Стандартлаштыра бару** Стандартлаштыру эшен әзлекле дәвам итү. *Бу хәл күп еллар дәвамында укыту системасын стандартлаштыра бару, чикләү, аның белән үзәк аша гына идарә итү һ.б. сәбәпләрдән килеп чыкты.* Фән һәм тел

**Стандартлаштыра башлау** Стандартлаштырырга керешү

**Стандартлаштырып бетерү** Стандартлаштыру эшен тәмам итү

**Стандартлаштырып җиткерү** Бөтенләй, тулысынча стандартлаштыру

**Стандартлаштырып карау** Булу-булмавын сынау максаты белән стан-

дартлаштыру. *Менә шуларның барысын да бер калыпка салып, стандартлаштырып кара инде.* Татарстан яшьләре

**Стандартлаштырып куюу** Тиз арада стандартлаштыру

**СТАНДАРТЛАШТЫРУ** II *и.* Билгеле стандартка туры китерү, әзер өлгегә, әзер калыпка салу эше һәм процессы. *Хәзер Фоат Дәүлиевич Казан ветеринария академиясенең биотехнология һәм стандартлаштыру факультетында студентларга белем бирә, доцент.* Р.Корбан

**СТАНДАРТЛАШУ** *ф.* 1) Стандартка (*1 мәгъ.*) туры килә башлау; стандартка (*1 мәгъ.*) әйләнү

2) *күч.* Бер формада катып калу, искереп иҗади үзенчәлеген югалту, шаблонга әйләнү. --- *сәнгатьләрнең үзара йогынты мөнәсәбәтендә яшәүләре аларның стандартлашуы түгел.* К.Гыйззәтов

**Стандартлаша бару** Акрынлап стандартлашу

**Стандартлаша башлау** Стандартлашу юлына басу; стандартлаштырырга керешү

**Стандартлашып бетү** Тулысынча стандартлашу; бөтенләй стандартлашкан хәлгә килү

**Стандартлашып җитү** Тулысынча, тәмам стандартлашу

**СТАНДАРТЛЫ** *с.* Билгеле стандарт (*1 мәгъ.*) буенча эшләнгән; билгеле стандартка туры килә торган. *Әйтик, «Евро» стандартлы машиналар өчен база ставкасы үзгәрмәячәк.* Ватаным Татарстан. *Бу системада халыкара стандартлы ике диплом алу мөмкинлеге бар.* Кызыл таң

**СТАНДАРТЛЫК** *и.* 1) Стандарт (*2 мәгъ.*) булу

2) Бердәйлек, бертөрлелек, шаблонлылык. *Гомумән, стандартлык, уртачалык – социализмның иң зур чирләреннән берсе, ахры.* М.Вәлиев. *Охшашлык, бертөрлелек, стандартлык безне ваемсыз, салкын канлы итә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**СТАНДАРТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тиешле стандартка (*1 мәгъ.*) туры килми торган, стандарт буенча эшләнмәгән, түбән сыйфатлы. *Төзелешне тапшырганда, шактый гына стандартсыз тимер-бетон плитәләр калган. Кем кайтарткандыр аларны?* А.Гыйләҗев. *Стандартсыз кирпечләр. Стандартсыз шпал*

2) *күч.* Гадәти булмаган, яңа, көтелмәгән. *Стандартсыз ысул*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле стандарт (*1 мәгъ.*) кулланмыйча; стандартка (*1 мәгъ.*) туры китермичә

2) *күч.* Гадәти булмаган, яңача, көтелмәгән рәвештә. *Стандартсыз фикерләү*

**СТАНИ́НА** *и. рус* 1) *тех.* Турбина, мотор, экскаватор һ.б.ш. машиналарның хәрәкәтсез өлеше, калган механизмнары беркетелә торган нигезе, рамы

2) *хәрби* Артиллерия тубы, пулемёт һ.б.ш.ларның йөртүче рамы, лафет, станок (*4 мәгъ.*). *Тәресыман станина*

**СТАНИ́ЦА** *и. рус* Казаклар яшәгән җирләрдә зур авыл. *Берәр якындагы станицага һөҗүм итеп аласы иде.* А.Гыйләҗев. *Шәһәр халкын, тирә-як станица һәм авылларны тәэмин итү ихтыяҗы һөнәрчелекнең җанлануына китергән.* И.Нуруллин

**СТАНОВО́Й** *и. рус тар.* Россиядә 1917 елга кадәр стан (*4 мәгъ.*) полициясе башлыгы. *Становой тагын аяк тибеп кычкырды: «Кайда, кайсыгыз ул?.. Күрсәтегез миңа башлыкларыгызны!..»* М.Галәү. *Ә соң теге елны, Становой тентеп бар йортны Недоимка җыеп йөргән чакта, Туган телне нишләп оныттың?* Ә.Рәшит

**СТАНОВО́Й ПРИ́СТАВ** *и. рус тар.* *к.* **становой**. *Икенче көнне кыңгыраулар таккан мичәүле атларга утырып, становой пристав үзе килеп төште.* Г.Бәширов. *Становой пристав, нәзакәт берлән генә, үзенең ни өчен килгәнен, кайдан мәэмүр (чиновник) булганлыгын сөйләде.* М.Әхмәтҗанов

**СТАНО́К** *и. рус* 1) Сәнәгатьтә металл, агач һ.б. каты материалларны эшкәртеп, алардан берәр нәрсә эшләп чыгара торган машина, җайланма. *Завод эшчеләре иртәнге җидедә үк станогын кабыза, станок артыннан китмичә, аягүрә басып, сигезәр сәгать бер үк ялыктыргыч хәрәкәтләрне ясый.* Җ.Харисов. *Алга киткән илләрдә станок-җиһазларны һәр 7–10 ел саен яңартып яки алыштырып торалар, ә безнең кайбер автозаводлар әле дә сугыштан соң куелган станокларда машина чыгарып яталар.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Таякчык формасындагы сап очына аркылы беркетелгән бритвадан гыйбарәт кырыну әсбабы

3) Берәр төрле эш башкару өчен махсус җайланма. *Сарайларда, өй алларында җитен талкучыларның станок тавышлары гына ишетелеп тора: тек-тек, тек-тек...* М.Яһудин. *Китап басу станогы төзелеше ягыннан гади булган.* М.Ситдыйкова

4) *хәрби* Пулемёт, туп һ.б.ш. корал урнаштырылган нигез. *Ә менә бүләкләү кәгазендә нәрсәләр язылган: 1943 елның 24 декабрендә Братково һәм Мятли авыллары янындагы сугышларда танкка каршы граната белән станок пулемётын юк итте.* Ватаным Татарстан

5) Берәр җайланма яки аның аерым детальләре беркетелә торган нигез

6) *махс.* Рәсем яки скульптура ясаганда терәк буларак кулланыла торган агач өчаяк. *Станок графикасында рәссамнар үзләренең Тукай шигърияте мотивлары кагылган ассоциатив дөньяларын төрлечә интерпретацияләр һәм барлыкка китерәләр.* Р.Солтанова

7) *махс.* Кайбер физик күнегүләрне ясаганда тотыну, таяну өчен махсус җайланма. *Менә ул станок янында кара тиргә батып күнегүләр ясый, менә ул спектакльдә күргән биюләрне кабатлый.* Р.Батулла. *Биючеләргә аерым пианино кирәк. Көзгеләр алып кайттык инде, станок бар.* Аманулла

8) *театр* Сәхнә декорациясенең калкулык, басма кебек нәрсәләр ясау өчен хезмәт иткән өлеше. *Беренчедән, Казаннан спектакльнең сәхнәдәге бизәлеше – декорация корыла торган нигезен (аны театрда «станок» дип атыйлар) алып килергә онытканнар.* Сәхнә

9) Дәвалаганда, дагалаганда һ.б.ш. очракларда хайваннарны кертеп бастыру өчен тар җайланма. *Ат дагалый торган станок шикелле, ләкин шактый киң булган ояга урнаштырылган баганаһың тирә-ягындагы тоткаларына утыз-кырыклап кеше ябышкан,*

*тавышсыз-тынсыз кызу гына тирәли әйләнеп йөри иделәр.* Ш.Камал. *Атны бәйләп куйгач, Мәүлетдин, кабаланмый гына атлап, станок янына барды да, айгырны дагалау исәбе белән, кирәк-яраклар тутырылган тартма өстенә иелде.* З.Зәйнуллин

**СТАНОКЛЫ** *с.* Станокка (*5 мәгъ.*) беркетелгән, станогы (*5 мәгъ.*) булган. *Бернichә минуттан ул станоклы пулемётны сөйрәп кертте.* Г.Әпсәләмов. *Станция тирәсендә зениткалар, пирамидага куелган станоклы пулемётлар.* Х.Камалов

**СТАНОКЧЫ** *и.* Станок белән идарә итүче, станокта эшләүче. *[М.Әхмәтгалиев] --- 1941–1942 елларда --- Ленинград шәһәреннән (хәзер Санкт-Петербург) Казанга күчерелгән Калинин исемендәге заводта станокчы булып эшли.* Балачак энциклопедиясе. *Аның бригадасына йөздән артык станок беркетелгән. Йөз станокчыда йөз сорау.* Ватаным Татарстан

**СТАНСА** *и. сөйл. к.* **станция**. *Габбас шул атка утырып почтовый стансага китте.* З.Һади. *Ул бу юлы Атбасар стансасына барып, Россия транспорт һәм страховка җәмгыятенең агентлыгына яллана.* И.Салахов

**СТА́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Билгеле маршрут буенча йөри торган тимер юл поездлары яки башка транспорт чараларының тукталыш пункты. *Ташлытау станциясе булмаса, тормышны ничек алып барыр идең? Ташлытау станциясе җирнең үзәге икән.* М.Мәһдиев. *Тимер юл станциясенә кадәр булыр-булмас ике чакрым ара.* Р.Ишморатова

2) *сөйл.* Шундый ике пункт арасындагы ераклык, шуларның аралыгы. *Ачуланма, тагын бер генә станция барыйм әле.* Р.Вәлиев

3) *сөйл.* Шундый пунктта билет кассалары, көтү залы, пассажирларга төрле хезмәт күрсәтү урыннары һ.б.ш. урнашкан бина; вокзал. *Менә аның каршында карт юкәләр ышыгына яшеренгән кызыл түбәле станция, сарыга буяган җыйнак каралтылар һәм станциядән ике якка сырт буйлап еракка, бик еракка сузылып киткән тимер юл.* Ә.Еники

4) Халыкка нинди дә булса махсус хезмәт күрсәтә торган предприятие, учреждение. *Институт бинасында үткәрелә торган практик дәресләр күптән беткән иде, без ике айга якын кан тапшыру станциясенә йөри идек.* Х.Камалов. *Көннәрнең берендә аны шәһәрара телефон станциясенә чакырдылар.* М.Маликова

5) Электр энергиясе җитештерә торган зур сәнәга предприятиесе. *Атом станциясе төзүчеләрнең ялгышы, партиянең фәләненче корылтаена төгәллибез дип кабалануы һәм проекттагы хаталар коточкыч һәлакәткә китерә.* А.Тимергалин. *Моңарчы җимерек станция тирәсендә мәш килгән халык атом радиациясенең ни дәрәҗәдә булуын да белми.* З.Мәхмүди

6) Гамәли тикшеренү алып бара торган фәнни учреждение. *Метеорологик станция. Поляр станция*

7) Билгеле бурычлар үти торган космик аппарат. *Станция 2012 елның августында Марска кадәр барып җитеп, аның иярчене Фобоска төшеп утырып, аннан җиргә туфрак җибәрергә тиеш иде.* Н.Алан. *Марс планетасының иярчене Фобос өслегеннән грунт өлгеләрен алып кайтыр өчен, «Фобос-Грунт» исемле автомат планетаара станция җибәрелгән иде.* К.Шакиров

**СТА́ПЕЛЬ** *и. голл. махс.* Суднолар төзү, төзәтү һәм суга төшерү өчен авыш басма рәвешендәге нигез, фундамент. *Команда килеп җиткәндә, «Татария» төзелеп беткән һәм стапельдән суга төшерелгән иде инде.* С.Сабиров. *--- төзелеп бетә язган хәрби кораблар стапельләрендә килеш яңадан металл кисәкләренә туралалар, я металл кисәкләре итеп бәяләнеп, чит илләргә сатылалар.* Мирас

**СТА́РОСТА** *и. рус* 1) *тар.* Патша Россиясендә кечерәк административ-территориаль берәмлекнең (мәс., волостьның), авыл җәмгыятенең идарә итү вазифаларын башкару өчен сайлап яки билгеләп куелган кеше. *Ике карт тамга салды, староста мөһер басты да кәгазьне әткәйгә бирде.* Г.Ибраһимов. *Куегыз әле, мин нинди староста булыйм, ди. Минем бит грамотам юк. Кул да куя белмим.* Т.Гыйззәт

2) Уку йортында сыйныфның, төркемнең оештыру эшләре өчен җаваплы, сайлап куелган укучы. *Лекция башланыр алдыннан, бер хатын кереп, староста сайлатып чыгып китте.* М.Мәһдиев. *Староста буларак Гөлүсә, бер урыннан икенче урынга йөреп, эш барышын күзәтә, аспирант җитәкченең һәрбер сүзен үтәргә тырыша, үзе дә эшкә катнаша иде.* Х.Ширмән

**СТА́РОСТАЛЫК** *и.* Староста хезмәте һәм вазифасы. *Ә соңрак, 1918 елда, бик тә үгетләгәч, ул старосталыкка риза була.* Ә.Баян. *Ясаклылар һәм рус авылларында үз авылдашлары старосталык итә.* А.Әминов

**СТАРТ** *и. ингл. спорт* 1) Спорт ярышларының башлану моменты. *Әллә ни озак көтәргә туры килмәде: атлар, салмак атлап, юлга төштеләр, старт алырга тиешле урынга киттеләр.* К.Тимбикова. – *Чаңгы ярышына әзерләнегез, тиздән старт! – диде.* М.Сәлим

2) Узыш ярышын башлау өчен бирелә торган сигнал, команда. *Старт бирелде. Без, унбиш малай, барыбыз берьюлы алга ыргылдык.* В.Нуруллин

3) Очкыч аппаратның күтәрелеп китү моменты. *Канатларына кара тәреләр төшерелгән «Юнкерс» техниклар ремонтлап яткан самолётларга, ә икенчесе стартта очып китәргә әзерләнгән истребительләргә ташланды.* Р.Ибраһимов. *Иртәгә старт биреләсе дигән көнне «Восток-6» корабы командиры, инде урнашкан традиция буенча, стартчылар белән очрашты.* Ватаным Татарстан

4) Спорт ярышы башлана торган урын, сызык. *Ат чабышында катнашучылар мәйдан белән янәшәдә генә старт сызыгына тезелделәр.* Р.Мөхәммәдиев. *Спортчылар, мотоциклларын җитәкләп, старт мәйданына коелдылар.* Ф.Баттал

5) Спорт ярышы үзе. *Мин дә килеп болельщик булырмын, стартка да чыгармын әле.* С.Шәрипов

6) Берәр гамәл, эшчәнлек, вакыйга һ.б.ш.ның башлангычы, башлану

ноктасы, моменты. *Җитди стартлар алдында тору*

**СТА́РТЕР** *и. ингл.* 1) *спорт* Спорт ярышларын башлап сигнал, команда бирүче; стартчы. *Стартер, өлкән судья боерыгыннан соң, катнашучыларны күкрәкләрендәге тәртип номеры буенча старттан җибәрә.* Гасырлар авазы

2) Аэродром командасындагы очкычларның күтәрелүен һәм төшүен турыдан-туры очу кырында күзәтеп торучы белгеч. *[Өйрәнчек очучы:] Кузгалып киттем дә, яңадан туктап, кулны күтәрдем. Шуңа җавап итеп стартер миңа ак флаг күтәрде.* С.Баттал

3) *тех.* Эчке янулы двигательләрдә моторны кабызу өчен электрик җайланма. *Стартер биш-алты минут елаганнан соң, машина кабынып китте.* Ф.Яруллин. *Тугаев кабина ишегенә тотынды, үзе культбудка ягына карый, Байкин рульгә утырды да стартерга басты.* Х.Камалов. *Шофёр стартерга басты.* Д.Бүләков

4) *махс.* Очкыч двигателен кабызу өчен шуның үзендә яки җирдә урнашкан махсус механизм яки җайланма

**СТАРТЁР** *и. ингл. к.* **стартер**

**СТАРТЧЫ** *и. к.* **стартер** (*1–2 мәгъ.*). --- *«Восток-6» корабы командиры, инде урнашкан традиция буенча, стартчылар белән очрашты. Космик гигантны очышка хәзерләүче кешеләрне монда әнә шулай дип атыйлар.* Ватаным Татарстан

**СТАРШИНА** *и. рус* 1) Россия армиясендә: ротадагы сержант һәм солдатларның турыдан-туры начальнигы булган, кече команда составына караган кеше; шуңа бирелә торган хәрби дәрәҗә. *Ниһаять, бер старшина килде, боларны тезеп санатты да каядыр алып китте.* Х.Камалов. *Бүлмәдә шахмат уйнап утыручы сержант белән старшина үзләрен катлаулы, куркыныч эш көткәнлеген сизеп аягүрә бастылар.* Р.Батулла

2) Россия Хәрби диңгез флотында кече команда составына караган, сержантка тигез звание, шул званиедәге кеше. *Менә бу старшина (ике сызыклы, димәк, икенче статьялы старшина), бәлки, минем кебек үк авыл малаедыр инде.* М.Мәһдиев

3) *тар.* 1917 елга кадәр Россиядә берәр сословие, хәрби оешма, зур булмаган профессиональ төркем һ.б.ш.ның оештыру эшләрен башкару өчен сайлап куела торган кеше. *Шушы вакыйгадан соң Сапый старшина белән писарь урыс әллә кая качтылар: күздән югалдылар.* М.Галәү. *Татарларның йомышлыларыннан, башкорт старшиналарыннан Пугачёвка каршы отрядлар төзүне таләп итәләр.* С.Алишев

**СТАРШИНАЛЫК** *и.* Старшина вазифасы һәм хезмәте. *Габделкәрим хәзрәт Балтаев та, имамлыгын ташлап, Башкорт комиссиясенә эшкә керә, старшиналык дәрәҗәсенәчә күтәрелә, тылмач булып китә.* М.Гайнетдинов. *Анда зур мәдрәсә дәвам итә, волостьның идарәсе дә шунда тора, һәр сайлауда диярлек старшиналыкка да бу авылның байларыннан берсе эләгә.* Д.Вәлитов

**СТА́ТИК** *с.* 1) Статикага (*1–2 мәгъ.*) караган, тигезлек саклауга мөнәсәбәтле. *Аны пружинаның статик тигезләнеш халәтендәге статик озынаюы дип атыйлар.* Теоретик механика. *Статик торыш. Статик корылма*

2) *кит.* Бер хәлдә калган, үзгәрми торган. *[Тормыш] – туктаусыз үзгәреп, алмашынып торган бер диңгез. Шуңа күрә пролетариат әдәбиятында статиктан бигрәк динамик моментлар зур урын алалар.* Г.Ибраһимов. *Материализм тәгълиматы буенча чагылыш статик һәм тәмамланган акт түгел, бәлки туктаусыз хәрәкәттәге күренеш.* К.Гыйззәтов

**СТА́ТИКА** *и. гр.* 1) *физ.* Механикада тигезләнеш яки тикторыш халәтендәге җисемнәр, масса яки көчләр тигезләнешен өйрәнә торган бүлек

2) Хәрәкәтсезлек, торгынлык, тикторыш хәле. *Йөкләү схемасы, геометрик үлчәмнәре һәм материаллары бирелгән статика юлы белән билгеләнә алмый.* А.Вәлиуллин. *Портретны статикада сурәтләү*

3) *күч.* Активлык күрсәтмәү, алга китмәү, торгынлык; дәртсез булу, пассивлык. *Иҗатында статика күзәтелү*

**СТАТИСТ** I *и. гр.* Икенче пландагы, сүзсез рольне башкаручы актёр; массовкада катнашучы

**СТАТИСТ** II *и. нем. к.* **статистик** II. *СССР Азык-төлек әзерләү министрлыгының Кайбыч район бүлекчәсендә статист, финанслар буенча хисаплау эшләре мөдире булып эшли.* Р.Даутов. *Казанга килеп «Чаян» журналында эшли башлаганга кадәр ул --- район үзәгендә статист, шундагы газета редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли.* Р.Миңнуллин

**СТАТИ́СТИК** I *с.* Статистикага бәйләнешле, шуңа караган, шуңа нигезләнгән. *Бу чынында статистик чыганаклар белән расланмый.* Р.Сибагатов. *Эштә Тубыл губернасы һәм Әстерхан авылларында мәчетләр җимерелүгә карашлы кайбер материаллар һәм статистик белешмәләр бар.* М.Гайнетдинов. *Хәзер бетон ныклыгы статистик тикшерү ысулы белән билгеләнә.* Төзү материаллары

**СТАТИ́СТИК** II *и. рус* Статистика белгече. *Дөрес, әлегә кулда статистиклар, экономистлар санап чыгарган быелгы төгәл саннар юк.* Азат хатын

**СТАТИ́СТИКА** *и. гр.* 1) Җәмгыятьнең икътисад, мәдәният һ.б. төрле өлкәләрендә барган үсешенең санча күрсәткечләрен өйрәнә торган фән. *Бүген статистика мәгълүматлары буенча Русиядә басылган китапларның 15 проценты гына кибет киштәсенә барып җиткән.* М.Вәлиев. *Күптән түгел редакция статистика идарәсенең аңлатмасын бәян итте.* Д.Гыйсметдинов

2) Шул фән алымнары белән берәр хуҗалык тармагында, җәмгыятьтә алып барылган исәп-хисап; шуның саннар белән белдерелгән күрсәткечләре, мәгълүмат. *Үлемнәр, каберләр, кеше сөякләреннән ясалган статистика. Кабахәт, җирәнгеч статистика.* М.Мәһдиев. *Инглизләр килгәнче кыргый, надан халык алар идарә итә башлагач баеган, аң-белемгә, культурага ирешкән: һәр фикер, һәр әйткән сүз статистика белән дәлилләнә.* М.Юныс

3) Физика, механика, астрономия кебек төгәл фәннәрдә кулланыла торган фәнни тикшеренүнең махсус алымы. *Математик статистика алымы белән тел күренешләрен микъдар ягыннан өйрәнәләр.* Ф.Сафиуллина.

*Статистика методларын тел системасын һәм сөйләм материалын тикшерүдә куллану.* Х.Сәлимов

**СТА́ТОР** *и. лат. тех.* Генератор, двигатель һ.б.ш. электр машинасының әйләнми торган өлеше. *Электромоторның роторы терсәкле валга тыгызлап киертеп куелган һәм аның әйләнүен тәэмин итә, ә статоры шпилькалар ярдәмендә компрессорның корпусына беркетеп куелган.* Суыту машиналары һәм криоген техникасы

**СТА́ТС-СЕКРЕТАРЬ** *и. нем.* Чорына һәм иленә карап, төрле, гадәттә министр һ.б.ш. вазифадагы дәүләт эшлеклесен яки югары титулны белдергән сүз

**СТА́ТУС** *и. лат.* 1) *рәсми* Гражданның яки юридик затның рәсми рәвештә билгеләгән хокуклары һәм бурычлары даирәсе; хокук хәле. *Буыннар сызлау чире хатын-кызның сәламәтлегенә җитди зыян салып кына калмый, ә бәлки психологик хәленә һәм социаль статусына тискәре йогынты ясый.* Татарстан. *Моңарчы да Мәскәүгә карап яшәгән Касыйм ханлыгы 1681 елдан статусын югалта.* Сөембикә. *Икенчедән, Татарстанның Россия белән төзелгән договорлы махсус статуска ия республика булуы безне куандырды.* Шәһри Казан

2) Аерым шәхеснең коллективта тоткан урыны, башкалар арасындагы абруе, башкаларга психологик йогынты ясау дәрәҗәсе. *Рус зыялыларының «литературные посиделки», XX йөз башында «Шәрык клубы»ндагы очрашуларны хәтерләтеп тора иде безнең күрешүләр, рәсми статуска дәгъва итмәсә дә.* Т.Галиуллин. *Бу очракта шәех статусы генетик туганлык буенча атадан угылга күчкән була.* А.Тимергалин

**СТАТУС-КВО** *и. лат. юр.* Халыкара хокукта хәлләрнең билгеле бер моменттагы хокукый, сәяси һ.б.ш. яктан торышы. *Дөнья статус-квосын саклау өчен, Русиянең милли дәүләтләргә аерылу хәрәкәтен вакытсыз табалар.* Х.Миңнегулов

**СТАТУТ** *и. лат.* 1) *рәсми* Берәр оешма эшчәнлегенең төп кагыйдә һәм принципларын билгели торган положение, устав

2) Берәр орден белән бүләкләнү һәм аны йөртү тәртибен билгели торган кагыйдәләр җыелмасы. *Дан ордены статуты*

3) АКШ, Англия һәм башка кайбер илләрдә гомуми характердагы хокукый актлар, кануннар. *Парламент чыгарган статут*

**СТАТУЭ́ТКА** *и. фр.* Гадәттә бүлмәне бизәп тора торган кечкенә һәйкәл, сынчык. *Стенада яки сервант өстендә чит илдә вакытыңда үз кулың белән диңгез төбеннән-фәләннән, базардан алган берәр кабырчык яки статуэтка торырга тиеш.* М.Мәһдиев. *Ә инде аяклары арыслан тәпие рәвешендә эшләнгән язу өстәлендә статуэтка күргәч, исем-акылым китте.* А.Тимергалин

**СТАТЬЯ** *и. рус* 1) Билгеле бер юридик документ һ.б.ш. рәсми кәгазьдә тәртип номеры белән күрсәтелгән мөстәкыйль бүлекчә, параграф. *Шушы статьялар яңадан үз көченә кертелде.* Р.Сибагатов. *Чөнки аның һәр главасы, бүлеге, статьясы халык белән киңәшеп, килешеп язылган, дөресрәге, совет халкы үзе язган китап ул Совет Конституциясе.* Р.Миңнуллин

2) Финанс документының, бюджетның керем-чыгым төрен күрсәткән бер бүлекчәсе, параграфы. *Мин, яшь язучыларга бирелә торган статьядан акча алып, коридорга чыкканда, Риза абый юк иде, рәхмәт тә әйтә алмый калдым.* Т.Миңнуллин. *Китап бәясе, финанс хезмәткәрләре теле белән әйткәндә, бу статьяларның һәркайсына, аларның артуы-кимүенә турыдан-туры бәйле.* М.Вәлиев

**СТАТЬЯЛАП** *рәв.* Статьялар белән, статьялар рәвешендә. *Сметаны финанслаудан (бу очракта средстволар бюджет учреждениесен тотуга статьялап бүлеп бирелә) аермалы буларак, ведомстволарның максатчан программалары аша финанслау һәр бюджет учреждениесен халыкка бюджет хезмәте күрсәтүләр буенча конкрет нәтиҗәләргә ирештерү максатыннан чыгып хәл ителә.* Ватаным Татарстан

**СТАТЬЯЛЫ** *с.* Статьясы, статьялары булган

**СТАХА́НОВЧЫ** *и. тар. [шахтёр А.Стаханов исеменнән]* Социализм чорында зур күрсәткечләргә ирешкән эшче. *Стахановчы булам дип, тәртә аша сикерергә уйлаган.* Г.Кутуй

**СТАЦИОНАР** I *и. лат.* 1) Вакытлы яки күчмә булмыйча, даими эшли торган дәүләт оешмасы, бүлек һ.б.ш. *Диплом өчен генә укучылар стационарда да җитәрлек лә ул. --- Читтән торып уку стационарга җитми инде.* М.Юныс

2) Авыруларның дәвалануы өчен палаталары, ятаклары һ.б.ш шартлары булган (поликлиникадан аермалы буларак) медицина учреждениесе. *Кичекмәстән стационарга салу кирәк булса да, Гөлҗиһан аны хастаханәдә калдырмады, үзе белән өйгә алып кайтып китте.* Җ.Дәрзаман. *Хатын стационарда ята.* А.Яһудин

**СТАЦИОНАР** II *с.* 1) Оешмасы, урыны даими булган, күчмә түгел. *Ул дәвердә, укыту-өйрәнү максаты белән махсус фильмнар күрсәтүнең башлангыч чорында ук, ярдәмче интернат-мәктәп стационар кино куюны оештырды.* М.Вәлиев

2) Нинди дә булса урында даими яки озак була, тора торган, шуңа караган. *УАЗ-3303 автомобильләре базасында эшләнгән әлеге күчмә пунктлар почта элемтәләренең стационар бүлекләре булмаган, ерак, кеше аз яши торган районнарда хезмәт күрсәтәчәк.* Ватаным Татарстан

3) *кит.* Үзгәрешсез, даими, тотрыклы. *Җисемнең стационар хәле*

4) *махс.* Хәрәкәтсез, бер урынга беркетеп куелган, күчереп йөртелми торган. *Машинаныкын икегә кисеп ясалган ике цилиндрлы стационар моторлы.* Р.Нуруллина

**СТА́ЧКА** *и. рус* Предприятие яки оешмада эш бирүчедән яки хөкүмәттән нинди дә булса таләпләрне үтәүгә, шулай ук эштәге бәхәсне хәл итүгә юнәлтелгән массалы рәвештә эш ташлау күренеше; забастовка. *Бишенче елгы революция башлангач, Яков шундагы сүс туку фабрикасында стачкалар оештырган.* В.Имамов. *Казандагы 1905 елгы октябрь вакыйгаларына һәм,*

*Казан эшчеләренең октябрь стачкасы бастырылганнан соң, киң колач белән коралльы восстаниегә хәзерлек барган көннәргә туры килә [Ямашев] ---.* Р.Зарипова

**СТА́ЧКАЧЫ** *и.* Стачкага катнашучы

**СТЕАРИН** *и. фр.* Шәм, сабын, резин һ.б.ш. ясау өчен файдаланыла торган аксыл яки саргылт төсле ярымүтәкүренмәле майсыман матдә. *Парафин, стеарин, маргарин – алар, беләсең килсә, исемнәре үк бертуганнар!* Ш.Бикчурин. *Казан һәм Мәскәү эшмәкәре Козьма Васильевич Крестовниковның уллары Александр, Василий, Иван Казанда 1855 елда шәм, стеарин, сабын кайнату, гөлсирин җитештерү химия заводы оештыралар.* З.Мөхәммәтшин

**СТЕ́ЛА** *и. гр. махс.* Берәр истәлекле вакыйганы мәңгеләштерү өчен, вертикаль рәвештә куелган язулы таш плитә яки багана. *Авыл хакимияте янындагы мәйданчыкта зелпе куаклары һәм тимер чылбыр белән уратып алынган таш стела.* И.Хуҗин. *Шәһәргә керү юлында бу исем язылган гаять зур һәм мәһабәт стела куелган.* Т.Кәримов

**СТЕЛЛАЖ** *и. рус* Яруслы киштәләре булган ачык шкаф, тезелеп киткән киштәләр рәте. *Каршыяк стенада гади тактадан гына әмәлләнгән китап стеллажы.* Г.Бәширов. *Сыйныф тактасы өстендә махсус стеллажда телевизор һәм аның белән янәшә негатоскоп урнаштырыла.* А.Галләмова

**СТЕН** *и. гр. физ.* Механикада 1000 ньютонга тигез булган көч үлчәү берәмлеге

**СТЕНА** *и. рус* 1) Бинаның эчке өлешен тыштан аерып, каплап һәм түбәне күтәреп тора, шулай ук бина эчендә аерым бүлмәләр-бүлемнәр хасил итә торган ян кормасы. *Сул як стенада аллыгөлле чәчәкләр белән бизәлгән көянтәләр эленеп тора.* Р.Вәлиев. *Авыру шагыйрьнең хәлен белергә килгән Г.Кариев, мәсәлән, дәвалаучы табибтан Тукайның бары берничә көн генә гомере калуын ишеткәч, озак вакыт тыела алмыйча, стенага сөялеп үкси.* М.Арсланов

2) Ныгытма хезмәтен үти торган калын, биек койма рәвешендәге корылма; дивар. *Кремль стенасы буенда үскән юкә агачлары астындагы аулак эскәмиягә барып утырдым.* М.Юныс

**СТЕНГАЗЕ́ТА** *и. рус* Кулдан язып яки басма рәвештә эшләнеп, гадәттә стенага эленә торган җирле (башлангыч) җәмәгать оешмаларының (һәм администрацияләренең дә) органы. *Черногорский миңа ярышка багышланган стенгазета чыгарырга кушты.* М.Юныс. *Монда шактый гына язучылар, шагыйрьләр эшләсә дә, ни өчендер, «Китап» исемле өч метрлы стенгазетаның редакторы итеп мине билгеләделәр.* Ватаным Татарстан

**СТЕНД** *и. ингл.* 1) Экспонатлар, диаграммалар, газеталар һ.б.ш. күрсәтмә материаллар урнаштырыла торган күргәзмә җиһазы (гадәттә вертикаль куела торган махсус такта җирлек, аслык); шунда куелган материаллар. *Шәһәр музеенда шагыйрь тормышына бәйле ике стенд та бар.* Л.Хәмидуллин. *Пыжмара авылының үзәк урамы Сөләйман Мөлеков исемен йөртә, мәктәп музеенда аңа багышланган стенд бар.* Г.Мөхәммәтшин

2) Машина, аппарат, механизм кебекләрне җыю, сынау өчен махсус җиһазланган урын яки җайланма. *Эшчеләр таләп итүенә карамастан, моторлар сынауны махсус стендларга күчерү турында да кайгыртмагансыз.* Г.Әпсәләмов. *Стенд ысулы сәнәгать, күпер һәм гидротехник төзелеш өчен зур үлчәмле эшләнмәләр җитештергәндә кулланыла.* Төзү материаллары

**СТЕ́НКА** *и. рус* 1) Берничә шкаф, сервант, киштә кебек секцияләре булган зур бүлмә җиһазы. *Кунак бүлмәсендәге заказ белән эшләткән, почмак ясап торган диваны да, зәвыклы савыт-саба белән тулган стенкасы, идән келәме бәллүр шарлар җыелмасын хәтерләткән искиткеч люстрасы белән ярашып тора.* Шәһри Казан

2) *спорт* Вертикаль яки авыш итеп беркетелгән, кул белән тотынып менүтөшү яки башка күнегүләр ясау өчен баскычка охшаш спорт җайланмасы. *Гимнастик стенкага үрмәләү*

3) Нинди дә булса савыт, сыешлык яки куыш әйбернең ян ягы, тышчасы. *Орлык яралгысының тышкы япмалары, үсеп, орлык кабыгына әверелә, ә җимешән стенкасыннан җимеш тирәлеге ясала.* Биология. *Еш кына күзәнәк стенкасын лайла каплап ала, күзәнәкле формаларның байтагының тәне ком бөртекләре белән бизәкләнгән була.* Биология

**СТЕНОГРА́ММА** *и. рус* Телдән сөйләмнең, гадәттә берәр рәсми чыгышның эчтәлеген сүзен сүзгә җиткерә торган язмасы; стенография белән язылган текст. *Стенограмманы укып чыктым да кешеләргә ышанычымны югалта яздым.* Т.Миңнуллин. *Киңәшмәнең стенограммасы урыннардагы партия оешмаларына җибәрелә.* М.Әхмәтҗанов

**СТЕНОГРА́ФИК** *с.* 1) Стенографиягә (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтле, шуңа билгеләнгән, шундый үзенчәлеккә ия. *Бу әңгәмәне, кызганыч ки, мин стенографик тулылык белән хәтеремдә теркәзә алмам, әмма мәгънәсен төгәл итеп язам.* Р.Харисов

2) Стенография (*1 мәгъ.*) белән язылган. *Без бу стенографик язмалардан, цитата рәвешендә, кайбер чыгышлардан өзекләр, җөмләләр китереп узарбыз.* Р.Фәйзуллин. *Бәлки әле, Көнчыгыш министрлыгы архивларында Җәлил белән Розенберг арасында булган ул сөйләшүнең стенографик язмасын да (әгәр ул сакланып калган булса) табарга мөмкин булыр.* Р.Мостафин

**СТЕНОГРАФИСТ** *и. рус* Стенография белгече; стенографик ысул белән язу остасы. *Нәгыймә стенографистлар курсын тәмамлый, комсомолга керә, Каракүл комсомол комитетында бүлек мөдире булып эшли.* Татарстан яшьләре

**СТЕНОГРАФИ́СТКА** *и. рус* Стенографист хатын-кыз. *Безгә бик әйбәт стенографистка табып бирелде. Конференцияләрдәге чыгышларны бөтен күңелен куеп, җентекләп язып барды ул һәм пөхтә итеп төпләп китерде.* Г.Ахунов. *Күрәсең, стенографистка дөрес ишетмәгәндер.* Т.Миңнуллин

**СТЕНОГРА́ФИЯ** *и. ингл.* 1) Тиз язып барырга мөмкинлек бирә торган махсус билгеләр системасы; шул система белән тиз язу ысулы. *Абзыйны*

*бүлдермичә, ара-тирә үзенең дәфтәренә аерым җөмләләрне генә язып, «әйе, әйе, шуннан соң» дип, тегенең сөйләвен куәтләп торды, ә мин стенография белән язып бардым.* Х.Мәхмүтов. *Т.Миңнуллинның чыгышы яхшы булган булуын: стенография язмасыннан шулай күренә.* Р.Фәйзуллин

2) Шул язу системасына өйрәнүөйрәтү турындагы фән. *Ул [Галя] берөзлексез французча өйрәнә, стенография курсында читтән торып укый.* М.Мәһдиев. --- *ул биналар, МИД балансында калып, стенография курслары өчен хезмәт итә.* Я.Шәфыйков

**СТЕНОГРА́ФИЯЛӘҮ** *ф.* Доклад, нотык кебек җанлы сөйләмне стенография системасы белән язу, теркәү

**Стенографияли башлау** Стенографияләргә керешү

**Стенографияләп бетерү** Стенографияләүне тәмамлау

**Стенографияләп тору** Стенографияләү эшендә булу

**СТЕП** *и. ингл.* Идәнгә табан белән бәрә-бәрә ритмик тавыш чыгарып биелә торган кызу темплы эстрада биюе; чечётка. *«Чабата»ны степ стилендә биергә керәшен яшьләре генә өйрәтсә өйрәтә инде...* Туганайлар. *Әмма әле классик биюдән башка да бик күп төрле биюләр бар лабаса: фольклор биюләр, джаз биюе (аның эчендә генә берничә агым бар), степ, сальса, contemporary (бу заманча биюне Пина Баушның спектакльләрендә күрергә мөмкин).* Ялкын

2) *спорт* Физик күнегүләр өчен тәбәнәк эскәмия рәвешендә ясалган махсус басма, такта

**СТЕП-АЭРО́БИКА** *и. ингл. спорт* Адымнар ясау, махсус басмага – степка менү-төшү кебек күнегүләрдән торган ритмик гимнастика төре

**СТЕ́ПЛЕР** *и. ингл.* Кәгазь битләрен металл атламалар белән беркетеп кую җайланмасы. *Күпме дәфтәр, ручка, степлер бетерәбез – чуты юк, һәммәсе үзебезнең акчага алынган.* Татарстан яшьләре

**СТЕ́РЕО-** *гр.* Кушма сүзләрнең «күләмле», «стереоскопик» дигән мәгънәне белдергән беренче компоненты. *«Стереотрубадан күзәтергә тели микәнни?» – дип уйлап алды Мирхас.* Х.Камалов. *Стереоколонкалардан, кычкыру-чинау катыш калай каккан тавышлар чыгарып, нииндидер кыргый музыка агыла башлады.* Җ.Дәрзаман

**СТЕРЕОКИНО** *и. рус* Махсус эшләнеше аркасында күләмлелек, ерак-лык-якынлык тойгысы бирә торган кино тасмасы; гомумән, шундый фильмнар. *Стереокино экранындагы кошларның залга очып чыгар кебек тоелуы*

**СТЕРЕОМЕ́ТРИК** *с.* Стереометриягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Стереометрик мәсьәлә*

**СТЕРЕОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Элементар геометриянең фигураларны пространствога бәйле рәвештә өйрәнә торган тармагы

**СТЕРЕОСКОП** *и. ингл.* Ике яссы сурәтне бергә кушып, кабарынкы, күләмле итеп күрсәтә торган оптик җиһаз

**СТЕРЕОСКО́ПИК** *с.* Стереоскопиягә караган; шундый үзлеге булган

**СТЕРЕОСКОПИ́Я** *и. гр.* Стереоскопик кино яисә фото ярдәмендә күләмле булып тоела торган сурәтләр эшләү ысулы

**СТЕРЕОТИП** *и. лат.* **1.** 1) *махс.* Типографиядә җыелган текстның металл, резин яки пластмассага төшерелгән, кабатлап бастыру өчен кулланыла торган күчерелмәсе. *Бу корпуска матбаганың гәзит, журнал һәм хәреф җыю цехлары, цинкография, стереотип бүлеге кебек форма әзерли торган бүлешләре куелачак.* Ш.Самат

2) *күч.* Кешенең берәр күренешкә карата гадәтләнгән карашы, алдагы тәҗрибәсе, иҗтимагый шартлар тәэсирендә формалашкан мөнәсәбәте. *Алар инде стереотип булып канга сеңгән, сумала кебек ягылып, алга таба атларга бирмиләр.* Ә.Рәшит

3) *күч.* Искергән, катып калган күзаллау, карашлардагы стандартлык. *Паспорттагы штамп нәрсә инде ул? Стереотип, катып калганлык, формальлек кенә.* Л.Әбүдәрова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Типографиядә бастыру өчен кулланылган күчерелмәне кабатлый торган, шул басмадан үзгәрешсез басылган (китап һ.б.ш. тур.). *Төзәтелгән, өстәмәләр кертелгән, кабат эшләнгән, шулай ук стереотип һ.б. кабат басмалар була.* М.Вәлиев

2) *күч.* Гадәти, стандарт. *Юк, шагыйрь күнегелгән стереотип чишелешкә риза түгел.* Р.Миңнуллин

3) *күч.* Искергән, катып калган (фикер һ.б.ш. тур.)

**СТЕРЕОТИПЧЫ** *и.* Стереотиплар әзерләүче типография эшчесе. *Аның басмаханәсендә татарлар арасыннан югары квалификацияле җыючылар, басу һәм төпләү осталары, литография эшчеләре, хәреф кисүчеләр, хәреф коючылар, стереотипчылар күпләп җитеште.* И.Рәмиев

**СТЕРЕОФО́НИК** *с.* Стереофониягә нигезләп эшләнгән; стереофония күренешенә караган. *Стереофоник радиоалгыч. Стереофоник кино*

**СТЕРЕОФОНИ́Я** *и. гр. махс.* Авазны чыгарып яки кабат яңгыратып, аның таралу юнәлешен һәм чыккан урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул; шул рәвешчә пространствода аваз чыгару-яңгырату күренеше. *Бәлки, шуңа күрә дә ул икеләтелгән тәэсиргә – үзенә күрә стереофоник яңгырашка ирешкәндер.* М.Вәлиев

**СТЕРИЛИЗА́ТОР** *и.* Стерильләү, йогышсызландыру аппараты, җайланмасы. *Анда кем дә юк, бары тик электр плитәсендә стерилизатор гына, бызыр-бызыр килеп, бар көченә кайный.* Н.Әхмәдиев. *Медпунктта конфетларны сумкага тутырдым, акушерка Кафия апа кулына кайнатылган шприцлар белән тулы стерилизатор тотты.* Г.Галиев

**СТЕРИЛИЗА́ЦИЯ** *и.* 1) Стерильләү процессы һәм эше. *Алар күксел лампалар яктырткан бүлмә аша үттеләр. Монысы стерилизация өчен, һәртөрле микроб-бактерияләрне юк итү өчен эшләнә икән.* А.Тимергалин

2) Махсус операция юлы белән хайванны яки кешене үрчү мөмкинлекләреннән мәхрүм итү. --- *Этләр артуның сәбәбе шул: башкалада 2001 елдан бирле урам маэмайларын үтерүдән туктап, стерилизация генә ясый башлаганнар.* Татарстан яшьләре

**СТЕРИЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. к.* **стерильләү**. *[Яраны тегәргә дигән җепне]*

*кайнаттылар, медицина кушканча стерилизацияләделәр.* Ш.Бикчурин

**Стерилизацияләп алу** Тиз арада стерилизацияләү

**Стерилизацияләп бетерү** Тәмам, барысын да стерилизацияләү

**Стерилизацияләп кую** Алдан яки тиз арада стерилизацияләнгән итү

**Стерилизацияләп тору** Даими яки әледән-әле стерилизацияләү; стерилизацияләү процессында булу

**Стерилизацияли башлау** Стерилизацияләргә керешү

**Стерилизацияли төшү** Берникадәр, тагын да стерилизацияләү

**СТЕРИЛЬ** *с. махс.* Микроблары, бактерияләре булмаган; стерильләнгән. *Сөлек тешләгән урынны стериль бинт белән бәйлиләр.* Сөембикә. *Стериль чисталык кешенең табигый иммунитетын юкка чыгара, ди алар [галимнәр].* Татарстан яшьләре

**СТЕРИЛЬЛӘҮ** *ф.* 1) *махс.* Кайнату, кыздыру, химик эшкәртү һ.б.ш. юллар белән нәрсәнең дә булса микроорганизмнарын бетерү. *Кайбер нәрсәләрне стерильләү кирәк булыр.* Ф.Яруллин

2) *мед.* Хирургик операция ясау юлы белән кешене яки хайванны ясалма орлыксызландыру

**Стерильләп алу** Тиз арада стерильләү

**Стерильләп бетерү** Барысын да стерильләү

**Стерильләп кую** Алдан яки тиз арада стерильләнгән итү

**Стерильләп тору** Стерильләү белән мәшгуль булу; даими яки әледән-әле стерильләү

**Стерильли башлау** Стерильләргә тотыну

**СТЕ́РЛИНГ** *и. ингл.* Урта гасырларда Бөекбританиядә алтын һәм көмеш акчага закон белән билгеләнгән проба стандарты

**СТЕ́РЛИНГ ФУНТЫ** *и. ингл.* Бөекбританиянең рәсми акча берәмлеге

**СТЕТОСКОП** *и. гр.* Йөрәк, тамыр, үпкә һ.б. органнардан килгән шауларны тыңлый торган медицина әсбабы. *[Врач] кесәсеннән стетоскобын чыгарып, егетнең күкрәгенә куйды һәм берничә урыннан тыңлады.* А.Шамов. *Врачлар тагын пульсны санарга, стетоскоп куеп, йөрәкне тыңларга керештеләр.* Х.Камалов

**СТИ́КЕР** *и. ингл.* 1) Өстенә берәр мәгълүмат төшерелгән, ябыштырып куела торган кәгазь билге, этикетка һ.б.ш.

2) *информ.* Блогларда, статусларда урнаштыру өчен, гадәттә реклама характерындагы рәсем, сурәт

3) Карандаш рәвешендәге коры җилемнең яки ябыштыргыч пистолет эчендәге җилем таягының сөйләмдәге атамасы

**СТИЛЕТ** *и. ит.* Тар йөзле кечерәк хәнҗәр

**СТИЛИСТ** *и. ит.* 1) *әд.* Үзенә генә хас үзенчәлекле стиле булган язучы, стиль I (*2 мәгъ.*) остасы. *Бөтен иҗатын тулаем өйрәнгәннән соң, Алексей Николаевич Толстойның барлык урыс язучыларыннан да ныграк, аеруча тотрыклы стилист икәнлегенә --- тулаем инандым.* К.Миңлебаев. --- *тәрҗемәче үзе оста стилист булганда, андый «югалтулар» оригиналның гомуми эмоциональ яңгырашына сизелерлек зыян китермиләр.* Н.Гамбәр

2) Кешегә үзенә килешкән причёска, макияж, кием һ.б.ш.ларны сайлап, аңа үз стилен булдырырга ярдәм итүче белгеч. *Татар телендә чиста матур итеп сөйләшүе, нур чәчеп торган күзләре, стилист ясаган чәчләре, кигән киемнәре бигрәк тә килешле иде шул.* З.Фәйзрахманова

**СТИЛИ́СТИК** *с.* 1) Стильгә I (*2 мәгъ.*) караган, шуның белән бәйле. --- *авазлар кабатлану билгеле бер стилистик максатлардан чыгып эшләнмәгән очракта, аларның урынсыз кулланылуы ямьсез яңгыраш – какофония күренеше барлыкка килүгә сәбәпче була.* Г.Гыймранова

2) Стилистикага мөнәсәбәтле. *Аерым стилистик алымнар аша иҗтимагый-тарихи вакыйгалар һәм реаль чынбарлык тагын да ачыклана төшә.* В.Хаков

**СТИЛИ́СТИКА** *и. рус* 1) *лингв.* Тел белеменең тел һәм сөйләм стильләре турындагы тармагы. *Шунысы үзенчәлекле: Г.Ибраһимов хезмәтләрендә грамматика белән стилистика бик тыгыз кушылып бара.* В.Хаков. *Телнең кулланылыш үзенчәлекләрен стилистика фәне өйрәнә.* Ф.Сафиуллина

2) *лингв.* Тел һәм сөйләмнең тулаем стиль чаралары. *Икенчедән, Азатның шигъри сиземләве, шигъри фикерләве кульязмада ачык чагыла. Җитәрлек дәрәҗәдә йөгерек теле, үзенчәлекле стилистикасы бар.* Р.Миңнуллин. *Авторларның стилистикасы байый, киң планлыга әйләнә.* Ф.Галләмов

3) Төрле элемент, факторлардан торган тулы образ, шуннан барлыкка килгән тулаем тәэсир; нәрсәнеңдер гомуми күренеше. --- *концерт программаларының стилистикасы да җырчыны рухи яктан канәгатьләндерде, чөнки табигате белән ул – академик җырчы.* М.Макаров. *Стилистика ягыннан да яшь, гайрәтле һәм фикерен анык белдерүче Путин белән авыру, карт һәм кәгазьдән зур авырлык белән укучы Ельцин арасында аерма бик зур иде.* Кызыл таң

**СТИЛЬ** I *и. лат.* 1) Аерым бер чор, юнәлеш сәнгатенең яки бер авторның индивидуаль иҗат манерасының тулаем образын хасил итә торган гомуми үзенчәлек, билгеләрнең барлыгы. *Шулар ярдәмендә драма сәхнәгә яңа тема гына түгел, лирик-романтик стиль төсмере дә алып килә.* А.Әхмәдуллин. *Шундый ук күренеш шәһәр архитектурасында да күзәтелгән: әйтик, Казан мәчетләрендә рус бароккосы, классицизм стиле билгеләре чагылган.* Д.Исхаков

2) Берәр нәрсәгә хас булган үзенчәлек һәм билгеләр җыелмасы. *Татар халык җырлары стилендәге бу шигырь чылтырап аккан чишмә суы шикелле матур һәм тигез ритмлы яңгырый.* М.Максуд. *Кемдер аны нәкъ менә су стихиясе символы буларак кабул итсә, кемгәдер ул кытай, һинд стилендәге корылманы хәтерләтергә мөмкин.* Маяк

3) Эш алымнарына, билгеле бер эшчәнлек өлкәсенә хас үзенчәлекләр, билгеләр. *Тулысынча партия идеологиясенә хезмәт иткән оешманың эш стиле дә, табигый, партия дисциплинасына буйсынган булды.* Р.Фәйзуллин. --- *укыту-тәрбия өлкәсендә*

*үзенчәлекле стиле булган авыл мәктәбенә йөз белән борылыр вакыт җитте кебек.* И.Шәйхетдинов. *Бюрократик эш стиле*

4) Тел, сөйләм чараларыннан, мөмкинлекләреннән файдалану алымнарының билгеле бер язучыга, әдәби әсәр, юнәлеш яки жанрга хас булганнары. *Әдәби үзенчәлекләре, стиль башкалыклары, талантлары һәм характерлары ягыннан бөтенләй төрле-төрле булган бу ике карт язучының үзара булган мөнәсәбәтләрен һичбер аңламыйча, читтән генә карап торган кешеләр дә бу көрешүнең самимилеген сизмәскә һәм аңламаска мөмкин түгел иде.* С.Кудаш. *Татар әдәбиятындагы иҗади юнәлешләр һәм агымнар, стиль тенденцияләре хәрәкәте күз уңында тотыла, сюжет-композиция өлкәсендәге эзләнүләр игътибарга алына.* Д.Заһидуллина

5) Сөйләмне әдәби тел нормаларына туры китереп төзү осталыгы, фикерне сүзләр белән белдерү манерасы. *Раульнең стиле – логик төзек, динамик стиль. Сүзләренең егәре зур.* Р.Фәйзуллин. *Әмма монда чама хисе югалмасын һәм гади генә, аңлаешлы, чын татарча итеп әйтәсе урында ясалма стиль белән сөйләү булмасын иде.* Р.Юсупов. *Лаконик стиль. Югары стиль*

6) *лингв.* Әдәби телнең функциональ төре. *Әдәби стиль өчен генә түгел, гомумән сүз төрләнү кануннары бик нык унификацияләнү сәбәпле, татар теленә кушымча һәм бәйлек тавтологиясе хас түгел.* Х.Сарьян. *--- сүз кушу юлы белән яңа сүзләр ясалу ул гомумән әдәби тел үсеше, аның функциональ стильләре (фәнни стиль, публицистик һәм рәсми стильләр һ. б.) белән тыгыз бәйләнештә тора, чөнки төрле өлкәгә караган терминнар да татар телендә күбрәк сүз кушу ысулы белән ясала.* Ф.Хисамова

7) *спорт* Бер предметны охшаш нәрсәләрдән сизелерлек аерып торган һәм шул предметның асылын хасил иткән үзенчәлекләр, билгеләр, алымнарның җәмгысы. *Милена Ибәтуллина үзен 400 метрга ирекле стильдә йөзүдә иң җитезе дип таныты.* Әлмәт таңнары. *Ишкәк ишү стильләре*

8) Бер мода юнәлешен, әйберне икенчесеннән аерып торган үзенчәлекләр, билгеләр. *Нора шундый баш әйләндергеч биек үкчәле туфли кия торган иде. --- Мондый стиль хатын-кызлардан аерым бер йөрү рәвешен булдыруны таләп итә ---.* Р.Мирхәйдәров. *Ул --- гади һәм аңлаешлы тел белән сәламәтлек, гигиена, макияж, маникюр, стиль, табын әзерләү, хобби, мәхәббәт мәсьәләләре хакында сөйли ---.* Матур буласың килсә

9) Иҗтимагый тормышның, активлыкның билгеле чорга хас үзенчәлекләре. *Урынының җайлылыгы, табигатьнең гаҗәеп матурлыгы хуҗаны, инде таләпләренә җавап бирми башлаган йортны сүтеп, утызынчы еллар стилендәге шушы псевдомодерн йортны салырга мәҗбүр иткәндер.* Р.Мирхәйдәров. *Сугыштан соңгы яшәү стиле*

10) Кешенең берәр эшчәнлекне алып бару, эшләү, үзенең шәхси сыйфатларын сөйләмдә, киемдә чагылдыру һ.б.ш.да индивидуаль манера. *Бу – Сталин стиле, бу җаваплар аның нәкъ үзе төсле: кырыс, төгәл, ачык.* М.Мәһдиев. *Стиль – кешенең нәкъ үзе инде ул, дигән гыйбарә бар.* Р.Фәйзуллин. *Акырып-бакырып, өстәл сугып, эштән куам дип куркыту минем стиль түгел.* Ватаным Татарстан. *Эшлекле ир стиле. Аралашу стиле*

**СТИЛЬ** II *и. лат.* Ел исәбен алып бару ысулы. *1886 елның 29 августында, яңа стиль белән 10 сентябрьдә, әтисе Мөхәммәтгариф үлеп китә.* Ф.Галимуллин. *Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә туган, Габдулла Тукай иске стиль белән 1913 елның 9 апрелендә якты дөнья белән саубуллашкан.* Ә.Мәхмүдов

**СТИЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Үрнәк итеп алынган берәр стильнең билгеләрен, үзенчәлекләрен бирү; шул стильгә туры китерү

**Стильләштерә башлау** Стильләштерүгә тотыну

**Стильләштерә төшү** Бераз стильләштерү

**Стильләштереп бетерү** Барысын да стильләштерү; стильләштерүне тәмамлау

**Стильләштереп кую** Тиз арада яки алдан стильләштерү

**Стильләштереп тору** Даими яки әледән-әле стильләштерү; стильләштерү процессында булу

**СТИЛЬЛЕ** *с.* 1) Билгеле бер стиль I (*1 мәгъ.*) белән эшләнгән, төзелгән, тегелгән, бизәлгән һ.б.ш.; шул стильгә караган. *Соңгы вакытта «Казан утлары» битләрендә төрле стильле, төрле формалы шигырьләр күбәеп китте.* Р.Миңнуллин

2) Үзенчәлекле, башкаларга охшамаган, матур кыяфәте белән аерылып торган. *Йорт әле яңа, тышланмаган, стильле итеп эшләргә уйланылган.* Г.Ахунов

3) Эшчәнлегендә, гамәлендә, үзен тотышында билгеле үзенчәлек, алым, юнәлеш булган (кеше тур.). *Эчтәлектә ул һәрчак бер стильле, бер максатлы, бер юнәлешле.* М.Гайнетдинов

**СТИЛЬЧЕ** *и. к.* **стилист** (*1 мәгъ.*). *Моңарчы тиңе булмаган оста стильче һәм шигъри тойгылы прозаик иде ул. Әгәр Тукай телебезнең иксез-чиксез шигъри сүз байлыгын, аның матурлыгын, тапкырлыгын поэзиядә ачкан булса, шуларны ук Г. Ибраһимов прозада ачты.* Г.Бәширов

**СТИЛЯ́ГА** *и. рус сөйл.* Киенү, үзүзен тоту һ.б.ш.да кычкырып торган модага иярүче; манералары һәм зәвыгы гомуми кабул ителгәннәрдән нык аерылып торган кеше. *Ә муенына стиляга булып муенчак тагып кайткан.* А.Хәсәнов

**СТИ́МУЛ** *и. лат. кит.* Берәр эшкә кызыксыну, теләк уята торган сәбәп, этәргеч. *Теләгән фикере зур кодрәткә ия, ул – әсәрнең язылa башлавына сәбәп кенә түгел, ә аны ахырына кадәр җиткерүне таләп итә торган стимул да ---.* Р.Фәтхрахманов. *Әлбәттә, рус шагыйренең әсәре Г.Зәйнашева өчен билгеле бер дәрәҗәдә стимул, этәргеч булгандыр, дип уйларга кирәк.* Д.Нигъмәтҗанова

**СТИ́МУЛЛАУ** *ф.* 1) Берәр процесс, вакыйга, эшкә стимул, этәргеч бирү

2) Организмның, нинди дә булса органның эшчәнлеген активлаштыру

**Стимуллап җибәрү** Бераз стимуллау

**Стимуллап тору** Даими рәвештә стимуллау

**Стимуллый башлау** Стимулларга тотыну

**Стимуллый төшү** Бераз стимуллау; тагын да әйбәтрәк стимуллау

**СТИ́МУЛЛАШТЫРУ** *ф. ялг. к.* **стимуллау**

**СТИМУЛЯ́ТОР** *и. рус махс.* 1) Берәр нәрсәнең үсешенә стимул, этәреш бирә, тәэсирен көчәйтә торган матдә. *Жалобачы, менә шушы стимуляторны нәсел үгезләренең иснәп тә караганнары юк, дип яза.* Х.Камалов. *Яңа препарат – ферма терлекләренә бирелә торган азык рационында стимулятор буларак үзенә иң мактаулы урынны алды.* Г.Галиев

2) Теге яки бу тукымаңы дозалы ток ярдәмендә стимуллап тора торган прибор. *Көпшә караваt кырыена асылган сидек капчыгына кереп киткән, бер электр үткәргеч карчыкның баш очында эленеп торган индикатор-стимуляторга менеп киткән.* Р.Батулла

3) Спортчыларның физик һәм психик мөмкинлекләрен кискен рәвештә (гадәттә кыска вакытлы) арттыру өчен, организмнарына кертелә торган химик матдә; допинг

4) Гомумән берәр күренешне, хәрәкәтне, эшчәнлекне һ.б.ш. активлаштыру, стимул бирү ысулы, юлы, чарасы

**СТИПЕНДИАТ** *и. рус* Стипендия алучы зат. *Ахыр чиктә малаен колхоз стипендиаты иттерде, кыска вакытлы курсларда имтиханнарга әзерләтеп, ветеринария институтына урнаштырды.* Х.Ибраһимов. *Стипендиатлар арасында Кукмара балалар сәнгать мәктәбендә тәрбияләнүче Муса Гаянов та бар иде.* Ватаным Татарстан

**СТИПЕ́НДИЯ** *и. лат.* Югары яки махсус урта мәктәптә укучыга дәүләт, иҗтимагый фонд яки хосусый оешма тарафыннан даими биреп барыла торган акчалата ярдәм. *Һәр елны мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган алты шәкерт Хөсәеновлар стипендиясенә теләсә кайсы чит ил яисә Россия югары уку йортларында укырга хаклы була.* Л.Хәмидуллин. *Стипендия ашауга да тартып-сузып җитә иде.* Р.Вәлиев

**СТИХИ́Я** *и. рус* 1) Борынгы фәлсәфәдә табигатьнең төп элементлары – ут, су, һава һәм җирнең һәркайсы. *Дүрт стихия белән бәйле карашлар*

2) Туктатып, тыеп яки идарә итеп, юнәлеш биреп булмаслык көч рәвешендәге табигать күренеше. *Г.Ибраһимовта диңгез мәһабәт стихия рәвешендә, Ш.Камалда диңгезнең катлаулы холкын кеше холкына охшатып тасвирлау бар.* Г.Ахунов

3) *күч. кит.* Оешмаган, тәртипсез хәрәкәт итә торган иҗтимагый көч. *Бу табигый теләк стихия төсен алмасын өчен, хакимият конгресс үткәрергә мәҗбүр.* Т.Миңнуллин. *Шунсыз стихия, хаос – котылгысыз.* К.Гыйззәтов

4) *күч. кит.* Гадәтләнелгән-күнегелгән көндәлек шартлар, табигый, иҗтимагый чолганыш; мохит. *Кыска сөю дулкыннары эченә күмелеп яшәргә күнеккән стихия кешесе.* М.Җәләлиева. *Билгесез стихия белән очрашуга күпләр психологик яктан әзер түгел иде.* Р.Ибраһимов

5) Очраклылык, системасызлык, эзлексезлек. *Тәҗрибәле язучы вакыйгаларны тасвирлаганда, аларны фантазия стихиясенә («ничек элләкте шулай»га) калдырмый.* К.Гыйззәтов

**СТИХИ́ЯЛЕ** *с.* 1) Стихиягә (*2 мәгъ.*) караган, шуңа бәйле; стихия (*2 мәгъ.*) көчләренең хәрәкәте нәтиҗәсендә барлыкка килә торган. *Грузиягә дә стихияле афәттән соң акчалата ярдәм күрсәтте. --- Кем соң ул Әсхәт Галимҗанович?* Р.Миңнуллин. *Дөнья армияләрендә чама белән 25 миллион өрлектәй егет материаль кыйммәтләр җитештерү сферасыннан, ачлык, хәерчелек, стихияле бәла-казалар белән көрәштән читтә тора.* С.Шәрипов

2) Җәмгыять, кешеләр тарафыннан идарә ителмичә, тәртипкә салынмыйча, табигый рәвештә, үзеннән-үзе бара, була торган. *Тиз арада стихияле рәвештә милли оешмалар пәйда булды.* Т.Миңнуллин. *Анда [«Халык контроле»] сервисында гражданнар үзләренә комачаулаган төрле проблемаларга – начар юллар, ваемсыз торакчылар, стихияле чүплекләргә карата шикаять калдыра ала.* Е.Мельник

3) Уйлап эшләнмәгән, сукыр, очраклы. *Иҗат стихиясе белән чамасыз мавыгып киткән тәнкыйтьче иҗат эшенең стихияле процесс кына түгел, аек акылга нигезләнгән тырыш хезмәт тә икәнлеген онытып җибәрә.* Г.Ибраһимов. *Аларның дөньяны танып белүләре нечкә күзәтүчәнлеккә, стихияле материализмга һәм беркатлы диалектикага нигезләнгән булган.* Г.Дәүләтшин

4) Оешмаган; беркем тарафыннан да оештырылмаган, җитәкчелеге булмаган (иҗтимагый хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Ярсыган тоткыннар, берни белән исәпләшмичә, корал даулыйлар. Бу стихияле кузгалышның бөтен эшне харап итүе мөмкин иде.* Г.Әпсәләмов. *Мәгълүм ки, Тукай иҗатының тәүге адымы Җаекта башлана. Аның дөньяга карашы формалашып кына килә, үз чорына протесты стихияле рәвештә шунда туа.* З.Шәйхелисламов

5) Бик көчле, ихтыярга, акылга буйсындырып булмый торган

**СТИХИ́ЯЛЕЛЕК** *и.* Стихияле рәвештә барлыкка килү, булу, үтү үзлеге

**СТИХИ́ЯЧЕЛ** *с. к.* **стихияле**. *Икенчедән, бу фаҗига тирән лиризм белән дә сугарылган. Ә «лиризм, Гегель сүзләре белән әйткәндә, – романтик сәнгатьнең стихиячел бер сыйфаты...»* Р.Ганиева

**СТО́ИК** I *с. филос.* Стоицизмга караган, шуңа хас. *Кипр утравында күренекле философ – Афинадагы стоик философия мәктәбенә нигез салган Зенон туган.* М.Мәһдиев

**СТО́ИК** II *и. гр. филос.* Стоицизм вәкиле һәм тарафдары. *Борынгы грек философлары (стоиклар), беренче авазлар әйберләргә охшатылган, дип фараз кылганнар.* Н.Фәттах. *Бу терминнарны борынгы Рим философлары – стоиклар керткән.* Фән һәм тел

**СТОИЦИЗМ** *и. гр. филос.* Борынгы грек фәлсәфәсенең кешенең дөньяда булган зарурияткә аңлы рәвештә буйсынырга, хис-кичерешләр колы булмаска тиешлеген раслаган рационалистик юнәлеше

**СТОЛБНЯК** *и. рус мед.* Үзәк нерв системасын зарарлый, тартышу өянәге белән бара торган йогышлы авыру;

тартышу авыруы. *Мәсәлән, аерым бактерияләр тарафыннан барлыкка килгән һәм столбняк, ботулизм һ.б. авырулар китереп чыгара торган агулар зоотоксиннарга керәләр.* Агулы үсемлекләр

**СТОЛБНЯКЛЫ** *с.* Столбняк авыруы булган

**СТОЛЯР** *и. рус сөйл.* Агач эшләре остасы; балта остасыннан аермалы буларак, ваграк, җентеклерәк эшләрне башкаручы оста. *Әти столяр минем. Әби әйтмешли, ул ясаган өстәлурындыклар, җанланып, тыпыр-тыпыр биергә генә тора.* Ф.Шәфигуллин. *– Безгә бит столяр, балта остасы, һич югында, әзер нәрсәләрне машинада таратып йөрүче кирәк, – дип дәвам итте сүзен Сәет ---.* Т.Галиуллин

**СТОЛЯРЛЫК** *и.* 1) Столяр һөнәре һәм осталыгы. *Соңга таба, ниһаять, аңа Казанга кайтырга да юл ачыла, һәм ул, Бишбалтадагы Олы урамда ярым җимерек фатир табып, аңа ремонт ясап килеп урнаша, «Татарлар өчен столярлык китабы» яза.* З.Рәмиев

2) Столяр эшләре. *Әйе, чын-чынлап лаборатория. Барометр, термометр кебек приборлар, слесарьлык, столярлык станоклары бар.* Т.Гыйззәт. *Сөйләшкәч-аңлашкач, алар совхозның столярлык мастерскоена бардылар, калып ясарга такта бармы, юкмы икәнлеге белән кызыксындылар.* Н.Фәттах

**СТОМАТО́ЛОГ** *и. гр. мед.* Стоматология белгече; теш һәм авыз-казналык авыруларын дәвалаучы табиб; теш табибы. *Стоматолог Игорь Никитич белән дуслашып киттек.* Г.Галиев. *Курыкма, мин теш врачы түгел, алмыйм да, ямамыйм да. Болай гына карыйм. Теләсәң, стоматологка язу бирербез.* К.Булатова

**СТОМАТОЛО́ГИК** *с.* Стоматологиягә караган. *Стоматологик тикшеренүләр. Стоматологик җиһазлар*

**СТОМАТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның авыз куышлыгы, теш, казналык һәм шулар тирәсендәге әгъзаларның авыруларын тикшерә торган тармагы. *Мәскәүдә узган халыкара «Денталь-экспо» стоматология салонында беренче тапкыр Казан белгечләре тәкъдим иткән спиральле медицина компрессоры да күрсәтелде.* Д.Хәйретдинова. *Стоматология факультетында уку биш ел дәвам итәчәк.* Ватаным Татарстан

**СТОП** *ы. ингл.* **1.** Берәр хәрәкәт, эшгамәлне туктатырга кушып әйтелә. *Без туп-туры эчкә узмакчы булдык. Ләкин без беркатлы сабыйлар икәнбез әле. – Стоп, стоп! – дип туктатты безне каты чырайлы завуч. – Билетларыгыз кайда?* М.Мәһдиев. *Стоп, брат, без синең белән ни дип сүз куештык?* Ж.Дәрзаман

**2.** *хәб. функ. сөйл.* Берәр хәрәкәт, эшгамәлнең туктавын белдерә

**3.** *и. мәгъ.* Механизм, транспорт һ.б.ш.ларны моментында туктату кирәклеген белдерә торган сигнал, билге

**СТОП-КАДР** *и. ингл.* Экранда күрсәткәндә, хәрәкәттәге сурәтнең туктавы яки әкренәю эффектын барлыкка китерә торган кинематографик алым

**СТОП-КРАН** *и. рус* Тимер юл вагоннарында поездны кинәт туктату өчен куелган тормоз краны. *Буре чокырын узгач, Кшерка урманы башлана; менә шул ике арада вагоннардагы стопкраннарны ачып, тиз генә тышка сикерегез ---.* Ш.Маннур. *--- уз-үземне белештермәстән, атылып, тамбурга чыкканмын да, иң якын кешеләремнән аерылып китүемне яңа гына аңлагандай, стопкранга китереп басканмын.* Р.Рахман

**СТО́ПОР** *и. ингл.* Берәр механизмның хәрәкәттәге өлешен туктату яки билгеле торышта хәрәкәтсез тоту җайланмасы. *Смена алышыныр алдыннанмы, элегрәкме, стопор гайкасын бормадыгызмы?* Н.Фәттах

**СТРА́ЖНИК** *и. рус* 1) 1917 елга кадәр Россиядә иң кече дәрәҗәдәге авыл полицейские. *Ләкин шул вакыт капкадан берәү йөгереп килеп тә керде, стражникны бәреп тә екты. Карасак, Гыйбаш абзый икән!* Г.Бәширов. *Менә 1911 елның 30 гыйнварына каршы төндә, жандарм ротмистры командалыгы астында, йөзләп атлы стражник, җиде становой пристав һәм бер исправник мәдрәсәгә басып керәләр.* И.Нуруллин

2) Гомумән кече дәрәҗәле полицейский һ.б.ш. кораллы сакчы. *Кылычларын кыныннан чыгарып өскә каратып тоткан стражниклар сагы астында дүрт студент килә ---.* Ә.Фәйзи. *Алар менә нәрсә күрделәр: төрмә ишегалдында ике стражник инде бирегә алдан китерелгән Муса Җәлилне ерткычларча кыйнап торалар, тимер дагалы итекләре белән типкәлиләр.* Г.Әпсәләмов

**СТРАЗ** *и. нем.* Кургашлы пыяладан ясалган, ялтыравы белән кыйммәтле ташларны хәтерләтә торган ясалма таш. *Йомырканы фольга белән төреп, савытка салынган җилемдә әвәләп алабыз. Аннан икенче савытка бисер, страз салып, шунда да тәгәрәтеп куябыз.* Хезмәт даны

**СТРАТЕГ** *и. гр.* 1) Сугыш алып бару остасы, стратегия (*1 мәгъ.*) белгече. *Оборонадан һөҗүмгә күчүне борынгы стратеглар сугышта иң авыр эшләрнең берсе итеп санаганнар.* Ә.Еники

2) Зур тәҗрибәле оста сәясәтче; иҗтимагый-сәяси тормышның мөһим мәсьәләләрен хәл итәргә сәләтле җитәкче

3) *күч.* Һәр адымын уйлап, артык катлаулы яки үтә хәйләле юллар белән эш итүче кеше

**СТРАТЕ́ГИК** *с.* **1.** 1) Стратегиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Владимир Ильич Ульянов-Ленин «Бер адым алга, ике адым артка» дип аталган хезмәтендә большевиклар партиясенең тактик һәм стратегик бурычларын билгеле.* Т.Миңнуллин. *Гитлер һәм Вермахт командованиесе, шул җиңүдән файдаланып, үзләренең стратегик планнарын тормышка ашырырга тотыналар.* З.Зәйнуллин

2) Стратегия таләпләренә җавап бирә торган; стратегиягә хезмәт итә, стратегия максатында файдаланыла торган. *Әгәр хәрби конфликт, сугышмазар чыкса, финнар бу стратегик юлны ярты сәгать эчендә өзәчәкләр.* А.Хәсәнов. *--- егерме яшьлек Фоат Гариф улы Тулбаев, стратегик объект маякны Бандера бандасы һөҗүменнән саклаганда, 1948 елның беренче гыйнварында һәлак була.* Т.Кәримов

3) Зур, житди, иң әһәмиятле, гомуми. *Эш менә нәрсәдә: без күп вакыт бүгенгедән чыгып кына гамәл кылабыз – вазгыятьне анализлыйбыз, стратегик*

*юнәлеше тәгаенләнмәгән планнар корабыз һәм алды-арты уйланылмаган чараларда катнашабыз ---.* Р.Сафин. *Әллә соң дин әһелләре үз халкының тәрәккые өчен булдырылган милли идеядән бөтенләй читтә торырга тиешме? Ә бит әлеге төшенчәгә халык тормышының иң әһәмиятле, моңарчы гамәлгә ашырылмаган стратегик проблемалары салына.* З.Мансуров

**2.** *рәв. мәгъ.* Стратегиягә нигезләнеп, стратегияне күздә тотып; глобаль рәвештә, киң масштабта. *Курск дугасы сугышын планлаштыруда генерал Антоновның стратегик уйлау таланты искиткеч уңай нәтиҗә бирә.* З.Зәйнуллин

**СТРАТЕ́ГИЯ** *и. гр.* 1) Сугыш алып баруның иң югары осталыгы, зур сугышларга җитәкчелек итү осталыгы; сугыш фәне. *Илне сакларга, халыкны якларга шул стратегия кирәк.* М.Гайнетдинов

2) Иҗтимагый, сәяси көрәшкә җитәкчелек итү осталыгы; шул хактагы тәгълимат. *Карышу мөмкин түгел, ул [горком] – төп штаб, стратегия һәм тактика шунда эшләнә, һәр эшкә, хәлгә, вакыйгага, кешеләргә бәя бирелә.* Х.Камалов

3) Берәр эшчәнлек өлкәсендә алдан күреп эш итү, гомуми план төзү осталыгы; шул хактагы тәгълимат. *Мәскәүнең милли стратегия институты эксперт-аналитигы Яна Амелина фикеренчә, халык Мортазинга хакимият тарафыннан изелгән журналист буларак караса да, чынлыкта ул – сәяси уенчы.* Г.Галәметдин

4) Спорт уеннарында уенны алып баруның алдан төзелгән һәм уен барышында эзлекле гамәлгә ашырылган гомуми планы

**СТРАТИГРА́ФИЯ** *и. лат.* Геологиянең тау токымнары катламнарын өйрәнә торган тармагы

**СТРАТИСФЕ́РА** *и. лат.* Җир кабыгының утырма токымнардан гыйбарәт өске өлеше

**СТРАТОСТАТ** *и. рус* Стратосферага күтәрелү өчен аэростат. *Стратостатка утырып, күктәге зәңгәрсу болытлардан да югарырак күтәрелгән кеше дип уйламагыз: юк, ул андый күренекле кеше түгел.* А.Шамов

**СТРАТО́СФЕ́РА** *и. лат.* Атмосфераның тропосфера өстендәге катлавы. *Нәкъ шул елларда атаклы очучы Владимир Коккинаки, дөньядагы барлык биеклекләрдән дә биеккәрәк ашып, стратосфераны айкап төште.* Ф.Хөсни

**СТРАХОВА́НИЕ** *и. рус икът., юр.* Саулыкка, милеккә, шәхси иминлеккә зыян килгән очракта матди яктан тәэмин итү системасы; иминиятләштерү. *Морза имениесеннән кисәү генә калды. Ә нәрсәгә ирештек? Морзабыз элеккесеннән дә шәбрәк итеп таш пулат салдырды. Картлар сөйли: ул хөкүмәттән, янәсе, бик күп итеп страхование акчасы алган.* К.Нәҗми. *Шәһәребез шифаханәләрендә мәҗбүри медицина страхование полислары бирү дәвам итә.* Р.Мөхиярова

**СТРАХОВКА** *и. сөйл. к.* **страхование**

**СТРАХО́ВКАЛАУЧЫ** *и.* Страховка белән шөгыльләнүче, страховкалаучы кеше

**СТРЕЙЧ** *и. ингл.* **1.** 1) Сузылучан, гадәттә синтетик җепләр кушып тукылган тукыма

2) Нинди дә булса товарларны, йөкне төрү өчен кулланыла торган тартылучан пластик плёнка

3) Шундый тукыманың яки плёнканың сузылучанлык, эластиклык дәрәҗәсе

**2.** *с. мәгъ.* Сузылучан, эластик. *Ул үзенә берничә размерга зуррак соры пинҗәк, алсу төстәге стрейч чалбар кигән, ак күлмәге өстеннән сары шакмаклы галстук тагып куйган.* М.Кәбиров. *Моннан тыш сәнәгать паркындагы предприятиеләрдә көнкүреш өчен кирәкле полимер әйберләр, металл конструкцияләр һәм ишекләр, видеокүзәтү системасы, стрейч плёнкалар җитештерелә һәм теплицаларда чәчәк үстерелә.* Мәдәни җомга

**СТРЕЛЕЦ** *и. рус тар.* XVI–XVII йөзләрдәге Русь дәүләтендә махсус даими гаскәрдә хезмәт итүче. *Кама аръягындагы хәрби ныгытмалардагы стрелецларның беренче төркеме – урыслаша башлаган шляхтичлар – 1738–1739 елларда Шушма елгасы буена, аңа Куак суы килеп кушылган җиргә күчереләләр.* Җ.Рәхимов. --- *татар патшасы гына урыс стрелецларының башларын балта белән үзе чаба ала, урыс боярларының сакалын кайчы белән кырка ала.* З.Зәйнуллин

**СТРЕ́ЛКА** *и. рус махс.* Рельс буйлап йөри торган транспортны бер юлдан икенчесенә күчерү өчен механик яки автомат җайланма. *Ләкин поезд стрелкасына килеп җитәргә егерме-утыз метр калганда, Рөстәм солдатның күкрәгенә атты һәм стрелканы борды.* Г.Кутуй. *Вагоннар бер юлдан икенче юлга күчкәндә, стрелкалар да дыңгырдашып алдылар.* Э.Касыймов

**СТРЕ́ЛКАЧЫ** *и.* Стрелка күчереп торучы тимер юл эшчесе. *Поездлар төзүчеләр, вагоннарны ялгаучылар ялгышлык белән тәгәрмәчләр астында кала яисә вагон араларына кысыла, стрелкачылар да шундый язмышка дучар булгалый.* Р.Фәизов. *Әгәр стрелкачы сизгерлеген югалткан булса, тиз йөрешле пассажир поездының авариягә очравы бәхәссез иде.* Ватаным Татарстан

**СТРЕПТОКОКК** *и. лат.* Эренле шешләр һ.б.ш. авырулар китереп чыгара торган озынча яки шар формасындагы бактерия төре. *Эрозияне төрле йогышлы чирләр: стафилококк, стрептококк, эчәк таякчыклары --- һәм башкалар китереп чыгара.* Сөембикә

**СТРЕСС** *и. ингл.* 1) Кеше яки хайван организмының берәр тискәре факторга (салкын, ачлык, яра һ.б.ш.га) каршы җавап реакция буларак барлыкка килгән киеренкелек хәле. *Нурзиягезне терелтү өчен шок кирәк, стресс кирәк!* Ф.Баттал

2) Нерв системасының шундый киеренке хәл кичерүе. *Психологлар фикеренчә, имтихан – балалар өчен зур стресс, шуңа да бу вакытта аеруча игътибарлы булу сорала.* Шәһри Казан

**СТРИПТИЗ** *и. ингл.* 1) Артистларның бию барышында әкренләп чишенүеннән, ялангач тән күрсәтүеннән гыйбарәт эстрада тамашасы. *Кәтүкнең хатыны Нәҗияне дә алып, «Акчарлак» рестораныңа стриптиз карарга менеп китәләр.* А.Хәсәнов. *Чаллы шәһәренең*

*бер базарында ял көнендә өйлә тирәсендә бер төркем кызлар, кәттә машинадан музыка уйнатып, стриптиз биеделәр.* Шәһри Казан

2) Шундый тамаша күрсәтелә торган урын. *Стриптизда эшләдем һәм шул ук вакытта өйдәге рәхәтлекне искә төшерә идем.* Ялкын

3) *шаярт.* Чишенү. *Аңлашылды: боларының операциядән соңгы җөйләре тигезләнгән, шуны бер-берсенә күрсәтеп мактанулары икән. Менә кайда ул стриптиз!* Безнең гәҗит

4) *күч.* Артык ачылып китү, серне теләсә кемгә ачу гадәте яки гамәле

**СТРИПТИЗЧЫ** *и.* Стриптиз күрсәтүче. *Траутман никадәр генә ашкынмасын, үзе дә стриптизчыларның Олимпия формасын 2020 елдан да алдарак киячәкләренә ышанмый.* Шәһри Казан

**СТРИТБОЛ** *и. ингл. спорт* Баскетболга охшаган, өчәр кешелек ике команда бер үк кәрзингә туп кертүдән гыйбарәт, шәһәр урам-мәйданнарында уйнала торган хәрәкәтле уен; урам баскетболы. *Стритбол (инглизчәдән Streetball) – урам баскетболы.* Мәдәни җомга. *Менә җиде ел майда һәм сентябрьдә Актанышта стритбол (урам баскетболы) ярышлары уздырыла.* Актаныш таңнары

**СТРИХНИН** *и. гр.* Костыргыч чикләвек (көҗәлә) орлыгыннан алына торган көчле агу, медицинада бик аз дозаларда кулланыла торган төссез кристаллик матдә. *Секуринин алкалоиды, стрихнин кебек үк, үзәк нерв системасын ярсыта, ләкин көчсезрәк тәэсир итә.* Агулы үсемлекләр

**СТРОЙ** I *и. рус* 1) Хәрбиләрнең бер-берсенең ян ягына, янәшәсенә басып, сызык буйлап тигезләнеп тезелгән сафы; шеренга; рәткә тезелгән хәрби часть. *Майор строй каршында рәхмәт белдерә.* И.Гази. *Шәмси белән сакаллы сугышчы командующийның сүзләрен, гүя стройда тыңлагандай, аягүрә басып, дулкынланып тыңладылар.* Г.Бәширов

2) Сугышчан хәрәкәтләр һ.б.ш. өчен хәрбиләр, хәрби техника, гаскәри часть кебекләрнең билгеле рәвештә тезелү тәртибе. *Бар белгәне – өстән килгән приказларны уку, мондагыларын язу, солдат солдатка честь бирәме, роталар ашханәгә җырлап, тигез стройда үтәме... Кем устав таләп иткәнчә киенми?* С.Шәрипов. *Аланга җитәрәк туктап калган автобустан унлап кеше төште. Фронтовиклар. Әнә түшләрендә – орден-медаль планкалары... Стройга тезелеп киләләр.* Г.Гыйльманов

3) Сугышта турыдан-туры катнашкан хәрбиләр составы; шундый гаскәр хезмәте. *«Винтовка тота беләбез. Безне стройга алыгыз. Санитарлыкка бездән картраклар да табылыр әле», – дигәч, аларның икәвен дә стройга алдык.* Ш.Усманов

4) Гомумән, берәр эш өчен тезелгән кешеләрнең төзек рәтләре; колонна. *Анда [детдомда] кыйныйлар. Строй белән йөртәләр... Укол кадыйлар...* Г.Гыйльманов

**СТРОЙ** II *и. рус* Аерым бер дәүләтнең, җәмгыятьнең сәяси төзелеш системасы. *Шомлы вакытта халыкка нейтраль әсәрләр укытып, укучыны матбугат янында тотып-саклап торырга да, форсат чыккач, патшага, стройга каршы хәтәр әсәрләр яза башларга!* Р.Батулла. *Коммунистик стройда, динсезләр арасында яшәп, сез ничек сакланып калдыгыз икән?* Р.Вәлиев

**СТРО́НЦИЙ** *и. лат. хим.* Радиоактив изотоплары техникада кулланыла торган химик элемент; көмешсыман ак, җиңел металл. *Нигездә стронций-90 дип аталган радиоактив матдәдән торган атом болытын көзге җил төньякка таба куа, ул Чиләбе, Төмән, Свердловск өлкәләре өстендә әҗәл эзе калдырып, Котыпка таба үтеп китә...* Ф.Бәйрәмова

**СТРОФА** *и. гр. әд.* Шигырьдә билгеле бер метрик, ритмик, интонацион-синтаксик төзелешкә ия булган һәм рифма белән берләштерелгән кисәк; бер-берсенә ярашкан юллар бергәлеге. *Әсәрдәге һәр строфа адәм баласының чиксез тирән кайгысы, мәңге бетмәс хәсрәте хакында сөйли.* Ф.Урманче. *Билгеле булганча, «Туган тел» шигыренең менә бу дүртенче строфасын күп еллар буена китапларда бастырмадылар, имеш, анда Ходай турында искә алына ---.* Ф.Галимуллин

**СТРО́ФИКА** *и. рус. әд.* 1) Поэтика теориясенең строфалар турындагы тармагы. *Ритм, рифма, строфика һәм композиция мәсьәләләре уңышлы шигырьләр нигезендә анализлана.* Т.Гыйлаҗев. *--- яшь шагыйрьләр арасында оригинальлеккә, үз тавышын табуга омтылып, эчтәлек оригинальлеге турында бөтенләй онытткан килеш, рифмалаштыруда, үлчәү һәм ритмда, строфикада «яңалык» уйлап чыгару омтылышларын еш кына күрергә мөмкин.* И.Нуруллин

2) Шигырьнең строфаларга бүленеше, строфаларга бүленеш ягыннан төзелеше. *Татар шигыренең сурәтлелек байлыкларын үстерүгә Такташ ифрат зур өлеш кертте. Аерым алганда, ритм, рифма өлкәсендәге яңачалыклары, ачышлары белән татар шигърияте тиңсез баетты ---. Рифманы Такташ күп йөкләмәле итеп кулланды.* Т.Галиуллин. --- *Семён Липкин болай дип яза: «Габдулла Тукайның иҗаты белән күп еллар буе танышып киләсең һәм кинәт аның байтак кына әсәрләренең традицион Көнчыгыш строфикасы белән – ике юллы шигырь итеп язылганын яки газәл формасында булуын күрәсең...»* Ф.Галимуллин

**СТРУК** *и. лат.* Агач кайрысын кулдан каезлау, сыдырып төшерү, бүрәнәне беренчел эшкәртү өчен, ике тоткалы кәкре йөзле эш коралы; гөргеч; *русчасы*: **скобель**. *Остаханәсенә килеп керсәң, исең китәрлек: дивардагы киштәләрендә нинди генә ышкы, струк, чүкеч, эскәнҗә, өтерге, мин белеп бетермәгән тагын әллә ничаклы эш кораллары тезелешеп яткан булыр.* Р.Низами. *Таза-таза ир-егетләр тарткан ике куллы струклар, кәкре ышкылар күккә йомычка чөя.* Р.Газизов

**СТРУКЛА́У** *ф.* Агач өслекне струк белән эшкәртү, струк белән тигезләп шомарту. *Струкламаган тактадан җил-яңгыр тимәсенгә каккалап куйган лапас кисәге ул.* Г.Ахунов. *Лапас ягыннан чыш-чыш нәрсәдер струклаганмы, ышкылаганмы тавыш ишетелеп тора иде.* Р.Төхфәтуллин

**Струклап алу** Тиз арада струклау

**Струклап бетерү** Струклау эшен тәмамлау

**Струклап кую** Тиз арада яки алдан струклау

**Струклап тору** Әле, хәзерге вакытта струклау

**Струклый бару** Акрынлап барысын да струклау

**Струклый башлау** Струкларга керешү

**СТРУКТУР** *с.* 1) Нәрсәнеңдер эчке төзелешенә, структурасына мөнәсәбәтле. *Гади һәм кушма җөмлә берберсеннән төзелешләре белән генә, ягъни структур яктан гына аерылалар.* М.Зәкиев. *Бәлки, Мәгариф министрлыгына структур үзгәрешләр кертергә, статусын үзгәртергә, кайбер вәкаләтләрне аңа тапшырырга кирәктер.* Р.Миңнуллин

2) Структура ягыннан тикшерә, өйрәнә торган. *Лотман кебек галимнәр ныклап эшкәрткән структур поэтикага охшаш якларны да күрә.* Х.Миңнегулов. *Әсәрләргә структур анализ, идея-эстетик бөтенлектә бәя бирү кызыклы күзәтүләр ясарга, образның эволюциясендә яңа үзенчәлекләрне аерып чыгарырга мөмкинлек бирер иде.* Н.Гафиятуллина

**СТРУКТУ́РА** *и. лат. махс.* 1) Берәр нәрсәнең эчке төзелеше; бербөтенне тәшкил иткән өлеш-кисәкләренең үзара урнашу, бәйләнү тәртибе. *Монадалы структура эволюция барышында беренче барлыкка килгән дип санала.* Л.Мәүлетова. *Агротехника, туфрак структурасы, агачларның төрләре... Арслангали, кечкенә блокнот тотып, яшьләр каршында лекция укый.* Д.Каюмова

2) Шундый өлеш-кисәкләр хасил иткән нәрсә; бербөтен. *Концепт – катлаулы һәм күп билгеләмәле структура.* Ф.Хәсәнова. *Тавыш ярылары – гормоннарга бик сизгер структура.* А.Юнысова

3) Нәрсәнең дә булса оештырылу рәвеше. *Институтның структурасы*

4) Оешма, учреждение, орган. *Күрше республиканың Бүздәк һәм Чишмә район хакимиятләрендә мәдәният бүлеге дигән структура бөтенләй юкка чыгарылган.* Римзил Вәлиев. *Федераль власть органнары системасында милли үсеш, милләтара иминлек, этносларның үзара бәйләнеше мәсьәләләре өчен җавап бирүче махсус структура булдырырга кирәк дип исәплим.* Кызыл таң

**СТРУКТУРАЛИЗМ** *и. лат.* Гуманитар фәннәрдә (лингвистика, әдәбият белеме, этнография, тарих һ.б.ш.ларда) XX гасырның 20 нче елларында формалашкан, тикшеренүдә структур ысул, модельләү, семиотика, формальләштерү һәм математикалаштыру элементларын кулланудан гыйбарәт юнәлеш. --- *аның да телнең төзелеше белән аеруча мавыккан, ягъни структурализм кыйбласын алган чор иде бу.* И.Низамов. *Болай эш итүне структурализм өчен гомумән характерлы сыйфат дип санарга кирәк.* К.Гыйззәтов. *Америка структурализмы телне саф формаль тасвирлау белән шөгыльләнә.* Ф.Сафиуллина

**СТРУКТУ́РАЛЫ** *с.* Билгеле үзенчәлектәге структурасы, эчке төзелеше булган. *Егерменче елларда киң колачлы, катлаулы структуралы поэмалар бәйләмен язып чыкканнан соң, Туфан бернничә елга шигърият сәхнәсеннән югалып тора, биштәрен аркасына асып, ил буйлап сәяхәткә чыгып китә, күзәтә, өйрәнә.* Т.Галиуллин. --- *Казан ханлыгы катлаулы социаль структуралы дәүләт булып күзаллана.* Н.Гариф

**СТРУКТУРАЛЬ** *с. лингв.* Структурализмга мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Структураль метод әдәби әсәрнең структура-төзелешен өйрәнүне күздә тота.* Ә.Закирҗанов

**СТУДЕНТ** *и. лат.* Югары уку йортында укучы. *Черкасскидагы студентлар тулай торагында койка бушый.* Л.Янсуар. *КФУның Яр Чаллы институты каршындагы «Дубравушка» спорт һәм сәламәтләндерү комплексына актив студентлар җыелды.* Шәһри Казан

**СТУДЕ́НТКА** *и. рус* Хатын-кыз студент. *Мәктәптә укыганда да, студентка булгач та Гөлфая безгә һәрвакыт килеп йөрде.* Г.Әпсәләмов. *Алар [«Irada» ширкәте] мөслимәләргә сыйфатлы юбкалар, күлмәкләр, туникалар, сарафаннар, баш киемнәре, өс киемнәре тәкъдим итә. Коллекцияләр күбрәк студенткаларны күз алдында тотып ясала.* И.Фәизов

**СТУДЕНТЛЫК** *и.* 1) Студент булу хәле. *Безнең студентлык тормышы авыр да, кыен да, күңелле дә, кайгылы да.* Г.Кутуй. *Ниһаять, Муса Җәлил – Мәскәү дәүләт университетының әдәбият факультеты студенты. 3145 номерлы студентлык билеты, 1930 ел.* С.Ибраһимова

2) Студент булган чор. *Җитмешенче елларның башына туры килгән студентлык чоры хакында сөйләгәндә, тагын бер бик мөһим нәрсәне дә истән чыгармаска кирәк.* М.Вәлиев. *Шөкер, студентлык чоры, гәрчә аерым кыенлыклар булса да, нәтиҗәле узды.* Х.Миңнегулов

**СТУ́ДИЯ** *и. ит.* 1) Сынчы, рәссам остаханәсе

2) Рәссам, скульптор яки артистлар әзерли торган мәктәп. *Халык иҗаты йортында һәвәскәр рәссамнар өчен иҗат студиясе оештырырга мәҗбүр булдым.* Мәдәни җомга. *Театр студиясендә уку*

3) Күбесенчә яшь кадрлардан (артист, рәссам һ.б.ш.лардан) торган, уку һәм иҗат эшләрен бергә кушып алып барган сәнгать коллективы. *Әллә борыннары бик югары булды, әллә телләре артык коры, студия халкы аларны кабул итмәде.* А.Хәсәнов. *[Муса Җәлил] Әллә ничә журналның редакторы, булачак опера театрының студиясен төзүче иде.* Г.Ахунов

4) Кинофильмнар эшләп чыгара торган оешма; киностудия. *Әлеге студия чыгарган фильмнар да, нигездә, татар кулында булмады.* Р.Батулла. *[Әмирхан Еники] «Азер кино» (Баку) студиясенең районлардагы махсус вәкиле (1936–1937) ---.* Татарстан язучылары

5) Радио, телевидение тапшыруларын әзерләү, төшерү, тавыш яздыру һ.б.ш. өчен махсус җиһазланган бүлмә яки бина. *Әле профессиональ камера, профессиональ оператор тапканчы, мин һәвәскәрләрчә генә сине тасмага төшерим әле. Студия шартларында түгел, Батулла үз шартларында.* Р.Батулла. *Уфада тавыш яздыру студиясендә Айдарны очраттым, һәм ул*

*татар эстрадасында, төгәлрәге, аның төркемендә гитарада уйнарга чакырды.* Э.Фатыйхова

**СТУ́ДИЯЧЕ** *и.* 1) Студиядә (*2 мәгъ.*) укучы. *1939 елны студиячеләр, Казанга кайтып, опера театрын ачып җибәрәләр.* Р.Галиев. *Мин, яшь театр белгече, театр җитәкчелеге --- чакыруы буенча, коллективның яшь студиячеләре өчен дөнья театры тарихы фәненнән күзәтү лекцияләре уку максаты белән, беренче тапкыр Әлмәткә килдем.* И.Илялова

2) Студия (*3–5 мәгъ.*) хезмәткәре

**СТЮ́АРД** *и. ингл.* Баштан – диңгез пассажир судносында, хәзер пассажир очкычында пассажирларга хезмәт күрсәтүче һәм аларның иминлеге өчен җаваплы хезмәткәр. *Стюард булыр өчен дүрт ай укып чыгарга кирәк.* Ялкын. *Казан кызы Айла Светличных һәм Истанбул егете Җүнәйт Доган --- иң романтик һөнәр ияләре – стюардлар.* Шәһри Казан

**СТЮАРДЕ́ССА** *и. ингл.* Хатын-кыз стюард. *Франция ярларына якынлашып киләрәк, лайнерның үзе кебек үк зифа стюардесса юлчыларга кофе һәм татлы эчемлекләр өләшә башлауга, каршыдагы телевизорның тавышын көчәйтә төштеләр.* А.Тимергалин. *Җирдән күтәрелеп тиешле биеклеккә менеп җиткәнче үк, стюардессабыз миңа бер язу китереп тоттырды.* Р.Ибраһимов

**СУ** *и.* **1.** 1) Елга, күл, диңгез, океаннарны барлыкка китерә торган, водород белән кислородның химик кушылмасыннан гыйбарәт үтәкүренмәле төссез сыекча. *Елга суы кинәт ярларыннан чыгып, урап, ташкынланып үтәргә мөмкин.* М.Рафиков. *Зират яныннан чыккан чишмә суы, кечкенә генә инеш ясап, буага килеп тоташа.* Ф.Гарипова

2) Сусауны басу, дәвалану һ.б.ш. максатлар белән эчелә торган әлеге сыекча; шуңа берәр матдә кушылган эчемлек. *Йомырка агы салынган кайнар суны тышта тиз-тиз суытты да, авыру сабыйның хәлсез иреннәрен ачып, әз-әз йоттырды [әнисе].* Г.Ибраһимов. *Газлы су бир әле, чибәрем!* Г.Афзал

3) Инеш, елга, күл, диңгез һ.б.ш. гадәттә зур тирән объект. *Ай калкып акрын туадыр, Ир егет яуны куадыр, Ир булсаң, суны үткел – Суны үтеп мине тоткыл!* Дастан. --- *тәрәзәгә карыйм, туган як күренмәсме, дим. Зуррак су күзгә чалынса, Каспий диңгезе дип уйлап, йөрәк дөп-дөп тибә башлый.* Р.Вәлиев. *Зур су шаулый ерак-еракта!* Зөлфәт

4) Дым, юешлек. *Солы саламына су үткән.* Г.Бәширов. *Түбәдән су үтү сәбәпле, түбә ремонтланып, шифер белән ябылды.* Хезмәт

5) Кеше яки хайван организмының күзәнәкләрендә, тукымаларында һәм куышлыкларында була торган, гадәттә төссез яки саргылт сыекча; сүл. *Үпкәсеннән сары су суыртып тордык.* Шәһри Казан. *Ашказаны суы*

6) Җимешләр, яшелчәләр составында була торган сыеклык; шулардан агызып, саркытып, сыгып алынган сыеклык; сыгынты; сут. *Җимеш суын синең күз алдыңда сыгып, боз салып бирәләр, йоткан саен тәнгә рәхәтлек агып керә.* М.Юныс. *Барый абзый бәхетле елмайды, йотлыгып, нарасые алып кайткан каен суын эчте, әйтерсең ул шушы суны гына көткән.* З.Кадыйрова

7) Берәр нәрсәнең сыек эремәсе. *Без әле күп нәрсәне белеп бетермибез. Бәлки, ләм, күкертле су, саф һавада булу синең организмыңны бөтенләй үзгәртер.* Ф.Яруллин. *Татлы яратучыларга шуны гына киңәш итәм: ашаганнан соң авызыгызны содалы су белән чайкагыз.* Сәламәтлек

8) Эчендә берәр ризык пешерелгән, тозланган, кайнатылган, шуларның тәме, сүле, кисәкчәләре катнашкан сыеклык. *Витамин-мазар җитешмәүне булдырмас өчен, пешкән дөге, пешкән солы суы эчерткәннәр.* А.Хәсәнов. *Миненур: Шуңа [шешәгә] гөмбә суы сал да алып кер.* Д.Салихов

9) Җиләк-җимеш, үсемлек һ.б.ш.лардан ясаган татлы яки җиңелчә исерткеч эчемлек. *Галимә апа уранып кына чәй янына килеп утырды һәм, бераз коймак ашау белән бергә, әни кайнатып биргән карлыган суын эчте.* М.Гафури. *Әллә каян табып, сары кашык та алып кайттылар. Алардан эчелгән сары гөлҗимеш суы да, кунакка сакланган тары ярмасыннан пешерелгән ботка да кызны терелтергә ашыкмады.* Р.Рахман

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* 1) Бик нык юешләнгән, тәмам чыланып беткән. *Чокырлардан шуышып килгәнгә Йончытылган, шинельләр – су.* Ф.Кәрим. *Болытлар җир белән тоташкан. Балчык итек һәм ботинка олтаннарына сылана. Шинельләр, бүрекләр – лычма су.* С.Шакир. *Аның [малайның] аяклары гына түгел, җиңнәренә кадәр чыланып, лач су була.* Г.Сабитов

2) Көтелгән, тиешле куелыгыннан күпкә кайтыш; бик сыек (аш-су тур.)

◊ **Су агу** *шигъ.* Вакыт, гомер узу. *Заман кичте, сулар акты, Хәзер юк инде ялкын; Кызу сүнде йөрәктә, Мәңгелеккә инде ул салкын.* Г.Тукай. *Ул шушы авылдан соңгы тапкыр чыгып киткәннән бирле, байтак су аккан булса да, Сөләйманов бөтенесен дә бүгенге кебек хәтерли.* И.Гази. **Су астына җибәрү** Суга батыру; батырып һәлак итү. **Су астына китү** Бату; батып һәлак булу. *Узган елны бер авыл кешесен аты-ние белән алып китте боз. Үзен коткардылар, аты белән чанасы су төбенә китте.* Ә.Фәйзи. *[Давыл] туктамаса, безнең су астына китүебез дә бик ихтимал.* Ә.Касыймов. *Эзләүчеләр су астына киткән бер машина эзенә юлыккан.* Безнең гәҗит. **Суга салу** 1) Суга батырып үтерү, һәлак итү. *[Кыз – Таһирга:] Сөйлә безгә: сине суга салып, Кемнәр аердылар илеңнән*? Ф.Бурнаш; 2) Бәхетсезлеккә, һәлакәткә дучар итү. *Байлык вәгъдә итә бай сиңа, Шул байлыкка күңелең ымсына. Син кызыңны суга саласың, Син кызыңны утка атасың.* Ә.Ерикәй; 3) Тиешсезгә яки бик бәрәкәтсез файдаланып әрәмшәрәм итү. *Нәсимә дус кызларына ияреп берәр тиенлек көнбагыш яки сагыз алса, әнисе олыдан кубып тирги иде аны: авыр заманда бер тиене дә эшкә ярый, ә син аны суга салып йөрисең.* К.Нәҗми. *Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: халык дәвалаучыларына йөрү – вакыт үткәрү, акчаны суга салу, батып барганда саламга тотыну ул.* Безнең гәҗит; 4) Нинди дә булса начар уйлардан һ.б.ш. арыну, котылу. *Сәйдә дә моң-сагышын суга салырга уйлады*

*ахры, әмма ни гаҗәп, һәр китүеннән ул тагын да сагышлырак, ямансурак булып кайтты*... Г.Гыйльманов. **Судан коры чыгу** Күңелсез, катлаулы вакыйгадан югалтуларсыз, зарар күрмичә чыгу; гаепле булып та, җәзасыз котылу. *[Әхмәтҗан] башын юләргә чыгарып, судан коры чыкмакчы була.* Г.Толымбай. *Ул иртәгә үк бүгенге җыелыш турында Сакмановка хәбәр итәчәк. Бу тиле-миленең кушканын үтәмичә, судан коры чыгу юлын да өйрәтер «Игелек» хуҗасы.* Т.Галиуллин. *Фетнә барышында «зур гөнаһка чummаган» старшиналар судан коры чыгу җаен карый башлый.* В.Имамов. **Су кабу** *к.* **авызга су кабу**. *Акча турында су кап.* А.Әхмәт. **Су кебек эчү** 1) Бик яхшы укый белү. *[Фатима] русча һәм мөселманча язуларны, халык тәгъбиренчә, су кебек эчә иде.* Г.Ибраһимов. *Сүрәләрне әткәм су кебек эчә, өйгә иман нуры биреп, биш намаз укый иде.* Д.Каюмова; 2) Бик яхшы белү, нык үзләштергән булу (берәр телне, дәресне һ.б.ш.). *Бик тырыша, хәлфә биргән дәресләрне су кебек эчә идем, шулай итеп күңелне юата идем.* М.Гафури. *Өлкән сыйныфта укучылар гына түгел, башлангыч сыйныф укучысы да интернетны су кебек эчә, кирәкле информацияне бик тиз таба.* Мәгариф. **Су керү** *к.* **су коену**. *Рәхәтләнеп су кердек, комда кызындык, уеннар уйнадык, әрәмәдә карлыган, кура җиләге җыйдык.* С.Сабиров. *Бозаулар көткән чакта, иптәшләр белән су керергә төшә идек.* Ә.Айдар. **Су кичү** *юг.* Тормыш кыенлыкларын кичерү, җиңеп чыгу. *Йөр, әйлән бөтен җирне, сулар кич; Кеше атлы еланнар калмасын һич!* С.Рәмиев. *Авырлыкны, кыенлыкны ул [эшче хатын] күп күрде. Тау актарды, таш күтәрде, җир сөрде. Иленә яу, җиренә дау килгән чакта да Утлар узды, сулар кичте, ул җиңде.* З.Биишева. **Су коену** Юыну, сафлану һ.б.ш. өчен елга, күл кебек су эченә кереп коену. *Хәтта Мишәгә төшеп, су коенып чыгасыларым килә иде.* В.Нуруллин. **Су кушу** Төрле уйдырмалар һ.б.ш. өстәү, күпертү, арттыру. *[Хөсәен] сүзләренә су кушып, күзгә төтен җибәрә башлаган икән.* Г.Мөхәммәтшин. **Су төбенә җибәрү** *к.* **су астына җибәрү**. *Комсомолец Могилевич, төшәргә сигнал бирелгәч тә, корабтан сикерми, корабтагы әйберләрнең берсен дә су төбенә җибәрәсе килми, барысын да коткарып калырга тырыша.* А.Алиш. **Су төбенә китү** *к.* **су астына китү**. *Сөйгәне белән су төбенә китеп барган Сайдә авылдагы хәтәр хәлләрне белмәве белән бәхетле иде.* Г.Гыйльманов. **Су урынына эчү** *к.* **су кебек эчү**. *[Әлмәттә яшәүче Альбина Насыйрова] Математиканы су урынына эчә.* Гаилә һәм мәктәп

**СУАЛЧАН** *к.* **селәүчән**. *Корсакны җир асты суалчаннары кытыклый.* Р.Нуруллин. *Суалчанның хәрәкәте тәненең алгы өлешендәге боҗра мускулларның кыскаруыннан башлана. --- Суалчанның корсак ягында тыгыз үсентеләре – төкләре була.* Биология

**СУ́ АНАСЫ** *и. миф.* Суда, гадәттә елгада яши, озын чәчле хатын-кыз кыяфәтендә була, дип ышанылган явыз зат. *Аһ, харап эш! Су анасы да минем арттан чаба.* Г.Тукай. *Су астында ул тән тагы да ак күренә, әйтерсең су анасы үзе. Су анасын шулай ап-ак тәнле диләр.* М.Хәбибуллин. *Су өстендә сыек томан. Шомлы талгынлык тирә-якта. Буа эченнән менә-менә су анасы чыгар сыман.* Р.Батулла

**СУБ-** *лат.* 1) *геогр.* Кушма сүзләрдә «астындагы, янындагы, буендагы, янәшәсендәге» мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *субарктик, субстратосфера, субтропик* һ.б.ш.)

2) Кушма сүзләрдә «буйсынган, карамагындагы» мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *субинспектор, субординатор, субконтинент*)

3) Кушма сүзләрдә «ярдәмче, икенчел» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк

**СУБАЙ** *и. рус* Күпчелек очракта сулы-сазлы җиргә яки йомшак нигезгә салынган корылмаларны күтәреп тора торган багана, терәк. *Галиулла субай сугучыларга да, бүрәнә төяп китүчеләргә дә артык әһәмият бирмәде.* А.Алиш. *Субай каккандагы сыман, аяк аслары тетрәп китә.* А.Тимергалин

**СУБАЙЛЫ** *с.* Субайлап эшләнә, шуның өстенә корыла-салына торган. *Субайлы күпер. Субайлы буа*

**СУБАЙЛЫК** *и.* **1.** Субай өчен билгеләнгән, субайга ярарлык булган материал. *Күпер янына субайлык кайтарып ташлау*

**2.** *с. мәгъ.* Субай өчен әзерләнгән яки шуңа ярарлык, җитәрлек булган. *Субайлык агач*

**СУБАЙЧЫ** *и.* Субай сугу эшендә эшләүче. *[Завод фундаментын салучы] субайчыларның түгәрәк сан – ике йөз меңенче субайны сукканда да мәшәкатьләре җитәрлек булды.* Казан утлары

**СУБКУЛЬТУ́РА** *и. лат. кит.* Аерым иҗтимагый, профессиональ яки башка төркемгә хас культура; гомумән, культураның бер өлеше. *Бүген андый субкультуралар саны бихисап.* Безнең гәҗит

**СУБОРДИНА́ЦИЯ** *и. лат.* Хезмәт дисциплинасы кагыйдәләре нигезендә кече дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең югары дәрәҗәдә булганнарга рәсми буйсыну системасы. --- *сорау, беренче карашка тоелганча, артык гадиләрдән түгел иде. Аның рәсми рәвештә баруы турында сүз дә булырга мөмкин түгел: заманалар башка, субординация буенча да бу мөмкин түгел ---.* Р.Мирхәйдәров. *Без – Алтын Урда халкы дәвамчылары, хәрби тәртипләргә буйсыну, субординация саклау – каныбызда.* Казан утлары

**СУБСИ́ДИЯ** *и. лат.* Гадәттә дәүләт тарафыннан юридик яки физик затларга бирелә торган акчалата яки натуралата ярдәм. *Начальник абый-энеләренә субсидия бирелми, дигән закон юк ич ләбаса.* Н.Вахитов. *Субсидиянең уртача күләме бер гаиләгә 1104 сум туры килгән.* Яңарыш

**СУБСИ́ДИЯЛӘҮ** *ф.* Субсидия бирү. *Үзебезнең ил һәм чит ил җитештерүчеләре техникасы һәм җиһазлары лизингка 1–5 ел срокка, лизинг килешүе буенча түләүләр субсидияләп бирелә.* Дуслык

**Субсидияләп тору** Әле, хәзер субсидияләү; даими субсидияләү

**Субсидияли башлау** Субсидияләргә тотыну

**СУБСТАНТ** *и. лат.* Предмет, әйбер, нәрсә. *Тылсымлы әкиятләрдән*

*аермалы буларак, җан мотивы бу төр халык әсәрләрендә [татар халык әкиятләрендә], тәнгә кереп-чыгып йөрергә мөмкин мөстәкыйль субстант буларак аңлану белән бергә, «тәнгә тереклек, хәрәкәт бирә торган башлангыч» мәгънәсендә кулланыла башлый.* Татар халык иҗаты

**СУБСТАНТИВ** I *и. лат. лингв.* Исем сүз төркеменә күчкән, исемләшкән сүз. *Субстантивларның еш кулланылуы*

**СУБСТАНТИВ** II *с. лингв.* Субстантивациягә бәйле, шуңа караган. *Фигыльнең субстантив формасы булган исем фигыльдә, мәгълүм булганча, исем билгеләре дә, фигыль билгеләре дә бер үк дәрәҗәдә чагылыш таба.* Ф.Хисамова

**СУБСТАНТИВА́ЦИЯ** *и. лат. лингв.* Сүзләрнең башка сүз төркеменнән исем сүз төркеменә күчү күренеше. *Окказиональ субстантивация. Вакытлыча субстантивация*

**СУБСТАНТИВЛАШУ** *ф. лингв.* Субстантивациягә дучар булу, исемләшү. *Мәсәлән, тамырдагы мәгънәнең субстантивлашкан нәтиҗәсен белдерүче (киңәшмә, оешма), җыймалык, гомумилек төшенчәсен бирүче (тынычлык, рәхәтсезлек, кешелек, кызыллык), бергәлек төшенчәсен белдерүче (сыйныфташ, юлдаш) кушымчаларның элеккегә караганда күбрәк кулланылуы, аларда яңа мәгънә төсмерләре артуы күзәтелә.* В.Хаков. *Исем фигыльләр бик җиңел субстантивлаша*

**СУБСТА́НЦИЯ** *и. лат.* 1) *филос.* Барлык предмет һәм күренешләрнең беренчел нигезен, асылын тәшкил иткән реаль чынбарлык, материя. --- *табигатьтәге һәрнәрсәне җанлы итеп күзаллау (анимизм) тәэсирендә җан гомумән мөстәкыйль субстанция буларак аңланган, ягъни кешенең һәм әйберләрнең җаны чыгып-кереп йөри дип исәпләнгән.* Татар халык иҗаты. *Без үзебез матди субстанция булганлыктан, матди дөнья турында гына белемлебез, шул хакта гына фикер йөртәбез һәм киләчәктә дә фәлсәфәбезне шул кысада дәвам иттерәчәкбез.* З.Мурсиев. *Рухи субстанция*

2) *кит.* Берәр нәрсәнең асылы, эчтәлеге. *Препарат әзерләнә торган субстанция кайвакыт бик ямьсез төстә булып, аннан начар ис чыга.* Шәһри Казан

**СУБСТРАТ** *и. лат.* 1) *махс.* Берәр нәрсә барлыкка килү, формалашу, оешу өчен нигез. --- *бу процесста да субстрат яисә күрше телләрнең тәэсире шактый зур роль уйный.* Фән һәм тел

2) *биол.* Берәр төрле организмнар үрчү, үсү өчен туклыклы мохит, зәмин. *Чүлмәк төбенә башта – дренаж (гравий, керамзит), аннан соң субстрат салыгыз. Субстрат һәрвакыт дымлырак булсын.* Шәһри Казан

3) *филос.* Барлык процесс һәм күренешләрнең гомуми материаль нигезе; бериш күренешләрнең охшашлыгына сәбәп булган гомуми нигез; субстанция. *Материя – дөньядагы барлык процессларның субстраты. Психик күренешләрнең материаль субстратын өйрәнү*

**СУБТРО́ПИК** I *и. лат-гр. геогр.* Көньяк һәм төньяк ярымшарларның тропик һәм уртача климатлы зоналары арасында урнашкан табигый поясларның берсе. *Субтропикларның климат үзенчәлеге. Субтропиктагы эсселек*

**СУБТРО́ПИК** II *с. геогр.* 1) Тропик һәм уртача климатлы зоналар арасында урнашкан табигый поясларга караган; тропик буендагы, шуның янәшәсендәге (географик урын тур.). *Ул гына да түгел, субтропик якларга хас булганча, тоташ яңгыр ява.* Р.Фәйзуллин. *Ыругта күбесенчә тропик һәм субтропик өлкәләрдә үсә торган 700гә якын төр исәпләнә, аларның кайберләре генә уртача төбәкләрдә очрый.* Л.Мәүлетова

2) Шундый өлкә, урын өчен хас. *Ялта – Көньяк Кырымның курортлар үзәге. Субтропик климат һәм шуңа хас гаҗәеп үсемлекләр дөньясы!* Г.Иделле. *Биредә субтропик климат шартларында таулар итәгендә ярымчүллекләр урнашкан.* Материклар һәм океаннар географиясе

**СУБУЯР** *и. биол.* Субуярчалар семьялыгыннан су өстен төрле төсләргә буйый торган вак суүсем, бака ефәгенең бер төре; *русчасы:* **водокрас**

**СУБУЯ́РЧАЛАР** *и. күпл. биол.* Субуяр, бака ефәге кебек үсемлекләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **водокрасовые**

**СУБҮЛӘР** *и. геогр.* Ике яки берничә елга бассейны арасындагы калку урын; *русчасы:* **водораздел**. *Монда субүләр үтә, Идел белән Вяткага коя торган елгалар шушында башлана.* Б.Хәмидуллин

**СУБЪЕКТ** *и. лат. кит.* 1) *филос.* Аң һәм ихтыярга ия, берәр объектка юнәлдерелгән максатлы эшчәнлеккә сәләтле зат; кеше. *Әйтик, табигать турындагы фәннәр (астрономия, физика, химия һ.б.) субъекттан азат.* К.Гыйззәтов. *Кешенең – тормышка, субъектның объектка мөнәсәбәтен революцион практика рәвешендә аңласак кына, тарихта шәхеснең ролен дөрес аңлаган булырбыз.* Г.Нигъмәти. *Субъект – фикер йөртә белүче зат ул, ягъни кеше*

2) Берәр процесста, вакыйгада актив катнашучы зат, кешеләр төркеме, коллектив яки оешма. *Тарих субъекты буларак ил. Коллектив – тәрбия объекты гына түгел, субъекты да*

3) *юр.* Билгеле хокуклары һәм бурычлары булган зат яки оешма. *Субъектның статусы бары тик Россия Федерациясе һәм субъектның үзара ризалыгы белән генә үзгәртелә ала, диелгән.* Ватаным Татарстан. *Хокук субъекты. Җинаять субъекты*

4) Билгеле сыйфатларга ия кеше, берәр үзенчәлекләре булган берәү. *Теге Гали кызыклы гына субъект икән*

5) *сөйл.* Тискәре сыйфатлары булган, күңелгә ошамаган, шикле кеше. *Аерым субъектлар [эшкә] комачаулый икән – аларны юлдан алып ташларга гына кирәк.* А.Расих. *Я, менә сөйләштегез, ничек соң шул субъект?* Н.Исәнбәт

6) *лог.* Хөкемнең предикат белән сыйфатлана, билгеләнә торган предметы, хөкем йөртелә торган нәрсә. *Хөкемнең субъекты һәм предикаты*

7) *лингв.* Җөмләдә ия яки гомумән башкаручыны белдергән грамматик форма

**СУБЪЕКТИВ** *с.* **1.** 1) Кеше аңында яши торган, субъект (*1 мәгъ.*) ихтыярына бәйле. *Бу юнәлешне объектив һәм субъектив төрләргә бүлеп эш итү сорала.* К.Гыйззәтов

2) Субъектка, шәхескә, аерым кешегә яки кешеләргә мөнәсәбәтле. *Милләтнең үз эчендә һәм төрле милләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә барган этник процессларның торышын һәрдаим күзәтеп һәм өйрәнеп торучы дәүләт һәм дәүләт оешмаларының булуы да мәслихәт. Алар милләтләрнең үсү процессында уңай яки тискәре роль уйнаучы субъектив фактор саналалар.* Татар халык иҗаты

3) Берәр кешенең үзенә генә хас; уртак яки гомуми түгел; шәхси. *Теге яки бу идеяне формалаштыруда аның [язучының] субъектив аерымлыклары шиксез зур бер роль уйный.* Һ.Такташ. *Әлбәттә, Еники карашында субъектив яклар өстенлек алган.* Р.Фәтхрахманов

4) Субъективизмга мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Субъектив идеализм. Социологиядәге субъектив метод*

5) Объектив булмаган, берьяклы; алдан ук бер генә фикерне, гадәттә тискәрене, күздә тотып якын килгән. *Чын мәгънәсендә үткен тел белән язылган, кайбер урыннарда шаяру катыш субъектив бәя, мөнәсәбәт тә үзен нык сиздерә торган бу язмалар җиңел-рәхәт укыла...* Д.Заһидуллина. *Тарихыбызны берьяклы, субъектив аңлатуга килешмәүчәнлек күрсәтергә тиешбез.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Объективлыкка нигезләнмичә, объективлык сакламыйча; алдан ук бер генә фикерне күздә тотып, берьяклы якын килеп. --- *этимология өлкәсе, никадәр генә тырышып баш-карсаң да, фантазиягә корыла, субъектив фикерләүгә урын калдыра.* Х.Садри

**СУБЪЕКТИВИЗМ** *и. нем.* 1) *филос.* Объектив чынбарлыкны инкяр итә торган, аны субъект аңында гына яши дип саный торган идеалистик юнәлеш. *Ләкин аның субъективизм кебек яман күренештән тәмам котылганы юк әле.* К.Гыйззәтов

2) *к.* **субъективлык**. *Кайбер чыгышларда әдипләргә килешеп бетмәгән дорфалык, субъективизм чалымнары булгаласа да, каләмдәшләр, күңелендәгеләрен яшермичә, ачыктан-ачык ихлас сөйләделәр, татар әдәбиятының киләчәге өчен борчылып чыгыш ясадылар.* Р.Фәйзуллин

**СУБЪЕКТИВИСТ** *и. рус* Субъективизм тарафдары. *Сез субъективист, сез анархист!* Р.Батулла

**СУБЪЕКТИВИ́СТИК** *с.* Субъективизмга нисбәтле; шуңа нигезләнгән. *Биредә бигрәк тә субъективистик (хаталы) хөкемнәрнең тискәре роле зур.* К.Гыйззәтов

**СУБЪЕКТИВЛЫК** *и.* Субъектив булу хәле, күренеше; субъектив шәхескә һ.б.ш. хас сыйфатлар. *Гадәттә субъективлык романтизм белән бәйләп карала. --- Ике гасыр чигендә буржуаз җәмгыятькә протест рәвешендә мәйданга чыккан экспрессионистик әдәбиятта субъективлык аеруча зур урын алды.* Н.Думави. *Билгеле, бу карашлар, материалистик диалектикага корылмаганлыктан, көпшәклеге, субъективлыгы белән характерлана.* К.Гыйззәтов

**СУВЕРЕН** I *с. кит.* Тулысынча бәйсез, суверенитетка ия булган (дәүләт тур.). *Татарстан Республикасы кайчан да булса башка республикалар, башка дәүләтләр кебек чын мөстәкыйль суверен дәүләт була алырмы?* Р.Миңнуллин

**СУВЕРЕН** II *и. фр.* Югары хакимияткә ия зат

**СУВЕРЕНИТЕТ** *и. лат. кит.* 1) Эчке һәм тышкы сәясәттә башка дәүләтләрдән тулы бәйсезлек һәм мөстәкыйльлек. *Нигә әле деколонизацияне суверенитет яулау һәм башка аллы-гөлле сүзләр белән алмаштырып маташабыз?* Н.Нәҗми. *Суверенитет даулаган елларда татарның дәррәү күтәрелеп алуы милләтнең исәнлеген, көрәшкә сәләтлелеген, потенциаль көчен күрсәтте.* Т.Миңнуллин

2) Нәрсәгәдер карата суверен (II) булу хәле, югары хакимият хокукы. *Дәүләтнең һава киңлегенә суверенитетка ия булу. Британия монархиясе суверенитетында булу*

**СУВЕРЕНЛЫК** *и. кит. к.* **суверенитет**. *Беренче нәүбәттә игълан ителгән дәүләт суверенлыгын ничектер законлаштырырга, ныгытырга кирәк иде.* Ә.Еники. *Цейлон дәүләте, аерылып, суверенлык алгач (1948 елда), аның беренче декретларыннан берсе фил аулауны тыю турында була.* М.Мәһдиев

**СУВО́РОВЧЫ** *и.* Суворов училищесы укучысы. *Арттарак басып торган ике суворовчы да, аның янына килеп, бөек рус полководецының төсле буяу белән ясалган рәсемен караватка куйдылар.* Г.Әпсәләмов. *Алар ал погонлы бер суворовчы малай артыннан чират алдылар да яр буена таба китеп бардылар.* Н.Фәттах

**СУГАН** I *и.* 1) Амариллисчалар семьялыгыннан әче исле, эфир майларына, витаминнарга бай көпшә кыяклы үсемлек. *Кайчандыр бакчаларга гына суган утырталар иде, бүген исә, пай җирләрен үзләренә рәсмиләштереп, гектарлаган мәйданда игәләр.* Ватаным Татарстан

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы коры кабыклы, әчкелт тәмле бер төбе, бүлбесе яки кыягы. *Нишләптер күзгә суган әчесе керә.* Р.Хафизова. *Әнкәй суган турый елап. Тактасы бик искергән.* Г.Мирһади

3) *к.* **суганча**

◊ **Суган сату** Буш, файдасыз сүз сөйләп вакыт әрәм итү; ләчтит сату. *[Гайнулла карт:] Печән базарына чыгып суган сатып гайбәт сөйләгән кебек булмас әле.* Ш.Мөхәммәдев. **Суган суы суыру** 1) Ачлы-туклы яшәү; ач булу. *Алар хәзер суган суы суырып утыралармы?* Һ.Такташ. *Чиле-пешле такмак язарга өйрәнү өчен, университетта суган суы суырып, биш ел гомер уздырып, кием туздырып, эт өрдереп, кеше көлдереп йөрүнең бер дә хаҗәте юк.* Г.Афзал; 2) Берәр нәрсәгә мохтаҗ булу. *Татар теленә бәйләнешле уйлап табу патенты, мөгаен, фәкать бездә генә бардыр... Шул ук вакытта үзебез менә монда суган суы суырып утырабыз...* З.Мифтахов

**СУГАН** II *и. бор.* Укның тимер башагы, очлыгы. *Угының суганы энәдәй булды, аның башы агулы иде.* Дастан

**СУГАНЛАНУ** *ф.* Суганның бүлбеләре барлыкка килү. *Суганның суганлана гына башлаганда тәмле булуы*

**Суганлана бару** Акрынлап суганлану

**Суганлана башлау** Суганланырга тотыну

**Суганлана төшү** Берникадәр суганлану

**Суганланып бару** Суганлануга таба үзгәрү

**Суганланып бетү** Тәмам суганлану

**СУГАНЛАП** *рәв.* Суган салып; суган белән. *Рәхми шул вакыт өстәл янында суганлап, тоз сибеп, кара икмәк ашап утыра икән.* Н.Исәнбәт. *Урта Азия, Кавказ халыклары гелән кухняда «милли» ит кыздыра, суганлап, борычлап пылау пешерә, без, татарлар, макарон төябез, аны да ипи белән ашыйбыз, туклыклы була, янәсе.* Р.Батулла

**СУГАНЛА́П-БОРЫЧЛАП** *рәв.* 1) Суган белән борыч салып, шуларны өстәп, кушып. *Әниләренә тоттырды [Биктимер абзый]: Ит пешер улыңа. Шулпа эчер суганлап-борычлап.* З.Зәйнуллин. *Ә сез беләсезме, суганлап-борычлап кыздырылган мәче – иң яраткан ризыгым!* Ш.Фәрхетдинов

2) *күч.* Бик каты һәм кискен (тәнкыйтьләү, шелтәләү, сүгү һ.б.ш.). – *Туры вахтага! – диде конвой начальнигы, суганлап-борычлап сүгенгәч.* И.Салахов. *Гөләндәм кабина ягына таба суганлап-борычлап берничә сүз әйтте дә сеңелесенә карады.* А.Гыйләҗев. *Гасыйм абый кешенең йөрәгендә бер эз калдырырлык итеп суганлап-борычлап сөйли дә үзеннән бер нәтиҗә чыгарып куя.* Х.Садрый

**СУГАНЛЫ** *с.* 1) Суган салынган, шуны кушып әзерләгән. *Тозсыз, борычсыз, чи суганлы, Идел суы – илле батман иттереп пешерелгән шул аш аз-аз гына костырмады.* Г.Исхакый. *Әни чыкты болгый-болгый камырлы-онлы кулын, суганлы сызык сумсасы ярата, диеп.* Р.Харис

2) Суганы булган; суган салгантөягән. *Суганлы капчык*

3) Суган уңган, суган уңышы булган (ел тур.). *Быелгыдай суганлы елны да суган бәясе күтәрелмәс инде*

4) *к.* **суганчалы**. *Түбән температуралар башланып, җир бераз туңа төшкәч кенә, суганлы чәчәкләрне каплап куярга кирәгер.* Өмет

**СУГАНЛЫ́-БОРЫЧЛЫ** *с.* 1) Суган, борыч һәм башка шундый тәмләткечләр салып әзерләгән. *Аннары коштабак белән калҗалап тураган ит килде. Җиңгәчәсе аның өстенә суганлы-борычлы кайнар өре салып җибәрде, һәм өйгә әчкелтем хуш ис таралып китте.* Ә.Еники

2) *күч.* Бик каты һәм кискен (тәнкыйтьле-шелтәле сөйләм, сүз һ.б.ш.). *– Чыдарлар!.. – дип, урысчалап, берничә суганлы-борычлы сүз кыстырды Барлас Камалов. – Кешеләр фронтта алтышар ел йөргәннәр…* Ф.Шәфигуллин. *Җәмилә аның артыннан суганлы-борычлы сүзләр әйтеп, мыскыллы көлеп калды.* С.Сабиров

**СУГАНЛЫК** *с.* 1) Суган күп итеп үстерелгән урын, басу

2) Суган алырга билгеләнгән яисә шуңа җитәрлек (акча тур.). *Бездән суган көнләшә. Мин гаепле, ялгыз калдым Суган кыягы белән... Суганлык та тормагач.* Р.Мөхәммәтшин

**СУГАНЧА** *и. бот.* Кайбер үсемлек сабакларының гадәттә туфрак астындагы суган бүлбесе шикелле калынайган өлеше. *Алар туклыклы матдәләрне я тамырчаларында, я суганча, я бүлбеләрендә көздән үк туплап, запаска җыеп куялар.* Ф.Ибраһимова. *[Сөмбел:] Верочка, икенче килгәндә, барысын да сөйләрмен, ә хәзер син безгә бакчага утыртырга күпьеллык чәчәк суганчалары бир әле.* З.Кадыйрова

**СУГАНЧАЛЫ** *и. бот.* Суганчадан үрчи торган. *Уңышны җыеп алудан кала, көннәр суыта башлаганчы, бакчаны тәртипкә китерәсе, суганчалы үсемлекләрне, карлыган, крыжовник куакларын сирәкләп, аларның чыбыкчаларын утыртып чыгасы бар.* Шәһри Казан

**СУГАНЧЫ** *и.* Суган үстерүче яки шуның белән сату итүче. *Тукай: – Кайда ул Петербургта бу һава белән яшелләкләр! Анда яшел нәрсәләрне суганчы марҗалар кулында гына күреп калырга була, – диде.* М.Гафури

**СУГАРГЫЧ** *и.* Сугару (*1–3 мәгъ.*) җайланмасы. *Су кирәгенчә генә ага торган чүлмәк сугаргычлар куела [фермада].* А.Расих

**СУГАРУ** *ф.* 1) Туфракка су сибү; суга туендыру. *Кайбер сугару системаларында су 15–20 км ераклыктагы иген кырларына аккан.* Г.Фәйзрахманов. *Аграр тармак белгечләре, бәрәңгене кичекмәстән туклыклы матдәләр белән тукландырырга яки сугарырга кирәк, дигән фикердә.* Ватаным Татарстан

2) Дымлы шартлар булдыру өчен, каналлар, арыклар һ.б.ш. үткәрү, төзү. *Чүлләрне сугару*

3) Су эчерү (терлеккә). *Үгезләрне сугардыңмы?* М.Гафури. *Рационда сусыл азыклар да булса, аларны [терлекне] сугарганчы ашаталар.* А.Расих

4) *күч.* Берәр төрле идея, караш рухын биру, шуңа буйсындыру. *Мәгърифәтчелек романтикасы белән сугарылган әсәрләр янәшәсенә, аерым бер төркем булып, Урта гасыр традицион романтизмы рухында язылган мәрсия, газәлләр килеп тезелә.* Р.Ганиева. --- *Камил Кәримов яшьлегендә төшенә башлаган су фәлсәфәсен әле дә булса өйрәнә. Ул хәзер халкыбыз күңелен сугару белән мәшгуль.* Г.Морат

5) *махс.* Кыздырып чүкегәннән соң ук салкын суга салып суыту юлы белән ныклыгын арттыру (металл әйберләр тур.). *Тимерчеләр, иске чалгы билен бөгеп [чакма тимере ясап], сугарып, чыныктырып бирделәр.* А.Гыйләҗев

**Сугара башлау** Сугарырга тотыну. *Сан ягыннан күпләп арткан илләрдә кешеләрне азык белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итү өчен, киләчәк буыннар комлы чүлләрне сугара башлар, шәт.* К.Сәгъдәтшин

**Сугара төшү** Тагын да сугару

**Сугарып бетерү** Барысын да сугару

**Сугарып тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта сугару. *Ашыт суы Шәмәрдән юлындагы әлеге болынны сугарып торган, безнекеннән аз гына киңрәк инеш икән.* Т.Нурмөхәммәтов

**СУГАРУЛЫ** *с.* 1) Сугарып игелә торган (культуралар тур.). *Сугарулы кәбестә утыртасы иде бу дымлы үзәннәргә.* Татарстан яшьләре

2) Сугарыла торган; сугарып кына файдаланырга мөмкин булган. *Сугарулы кыр-болыннар кирәк.* А.Гыйләҗев. *Татар әйтем-мәкальләрендә аеруча сугарулы елга буйларына гына хас күл, камыш, көймә, балык, балыкчылык еш телгә алына.* Н.Фәттах. *Сугарулы болыннарга мохтаҗлык зур.* Казан утлары

3) Сугару (*2 мәгъ.*) юлы белән эшләнә торган, шуңа нигезләнгән (игенчелек

һәм аның тармаклары тур.). *Урта Азия – иң борынгы сугарулы игенчелек районнарының берсе.* Ватаным Татарстан

**СУГУ** *ф.* 1) Кул яки берәр әйбер белән кискен бәрү. *Кадакны бер сугуда төбенә кадәр батыра аласыңмы?* Г.Әпсәләмов. *Их, әнә шулай күз көннәрендә эзләп табып, таяк белән сугып төшереп ашаган алманың тәмен белсәгез иде сез!* И.Гази. *Шулай аптырап утырганда, Хәбир йодрыгы белән идарә пультына китереп сукты.* З.Мәхмүди

2) *диал.* Кыйнау. *Шундый атны Кулың барып ничек сугасың?* М.Гафури. *Кызганмыйча сук шул явызларны.* Т.Гыйззәт

3) Суктыру, жәза бирү. *Габделкаюм караганда, озын өстәлгә йөзтүбән --- яткырып, берәүне сугалар иде.* М.Гали. *Хәзрәт колакны бора, суфи абзый илә казый, хаклы булсын, хаксыз булсын, һәр көн сыртка чыбык сугалар, иптәшләр көлә, мыскыл итә, чабата-башмакны урлыйлар.* Ф.Кәрими

4) Берәр нәрсәгә бәреп, яңгырау тавыш чыгару; кагу; бәрмә уен коралында уйнау. *Сары юрга урман читендә башын уйната-уйната, урта барыш белән, барабан суккан сыман тояк тавышлары чыгарып, онытылган Искәндәрне өенә алып кайта иде.* К.Тинчурин. *Аннары якындагы чиркәү манарасында чаң суккан тавыш ишетелде.* М.Галәү

5) Билгеле вакыт аралыгы саен берәр чыңлау, тавыш, музыка һ.б.ш. рәвешендәге сигнал бирү (сәгать һ.б.ш. тур.). *Мин күкеле сәгать сукканга уянып киттем.* Г.Бәширов. *Әнә Кремль курантлары сукканга да ике сәгать үтеп киткән инде, ләкин танышым һаман күренми.* Ф.Баттал

6) Ашлык башагындагы, кузагындагы бөртекләрне кагып кою, чыгару, алу. *Инде игенне сугып бетерергә дә күп калмады.* В.Нуруллин. *Менә син миең кибәрлек эсседә йон оекбаш киеп арпа сугуда эшләп кара.* М.Мәһдиев

7) Кирпеч, кизәк һ.б.ш. әйберләрне махсус калыпка салып ясау, эшләп чыгару. *Менә Әхмәт абый, йөзләп йортны көл иткән янгыннан соң, су буенда кирпеч суга башлады.* Р.Газиз. *Ә инде Наил абыйны эзләп килгән эшкуар, әлбәттә, әлеге техниканы тизәк сугарга түгел, башкала бакчалары өчен органик ашлама җитештерүдә файдаланырга тели.* Кызыл таң

8) Нинди дә булса металлны басу, кысу, чүкү юлы белән тиешле формага кертү. *Кем белә, сез может монда ялган акча сугып ятарсыз?!* Ә.Еники. *Чуен койган, тәңкә суккан, чүлмәк ясаган бабаларыбыз.* Ватаным Татарстан

9) Тугым кебек нәрсәләрне махсус җайланмада бөгеп ясау. *Сабирҗан агай тәгәрмәч суга торган станга утырды да ашыкмый гына күн альяпкычын салды.* М.Шәрифуллин

10) Туку (киндер, чыпта һ.б.ш.ны). *Хезмәт куркытмый аларны, анысы турында борчылмаска мөмкин. Чыптакап, киндер сугарлар, чабата тукырлар, кирәк икән, көнлекче эшенә дә ялланырлар.* М.Галәү. *Ул яз көне, менә хәзерге шикелле, башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кулъяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә.* Г.Бәширов

11) Кагып һ.б.ш. рәвешчә беркетеп кую. *Күпергә яңа өрлек сукканнар икән.* Х.Садрый. *Гел генә бөкреңне чыгарып, итеккә кадак сугып утырмассың бит, Сафа абзый да, вакыт-вакыт тураеп, аягына баса ---.* Ф.Хөсни

12) Канатларын шапылдатып кагу, җәһәт-җәһәт җилпү (эре кошлар тур.). *[Әтәч] читән башына очып менде дә, канатларын шап-шап сугып, бугазын киереп кычкырды: – Кикрикүк!* И.Гази

13) Келәймә, пичәт кебек нәрсәләрнең эзен, рәсемен, билгесен берәр өслеккә басып төшерү. *Аңа мөһер сугылган, штемпель белән кул куелган ич инде.* А.Тимергалин. *Инде чыгып барганда, Асия аңа «ашыгыч» дип тамга сугылган телеграмма сузды.* В.Имамов

14) Гомумән берәр билге, тамга кую, тамгалау, ишарәтләү. *Командир ул язуны укып карады да, почмагына резолюция сугып, штабка җибәрде.* Ш.Маннур. *Һәр кабердән чыккан сөякләргә номер сугып, махсус төзелгән такта сарайга һәрберсен аерым капчыкка салып куялар.* З.Зәйнуллин. *Ул үзенең кассасының номерын шул кәгазьгә сукты ---.* М.Исхаков

15) Җибәрү, бирү (телеграмманы). --- *Таңсылу Шәфкатия исеменә «Елдырым» линиясе буенча телеграмма сукты.* А.Тимергалин. *Ихтыяр телеграфка кереп, үзенең берничә көнгә тоткарлануы турында заводына телеграмма сукты да кунакханәгә кайтып егылды.* Р.Вәлиев

16) Ышкып я кырып тәнне, тирене җәрәхәтләү (камыт һ.б.ш. тур.). *[Ат караучы] барлык сбруйларны тикшереп чыкты. Камыт, ыңгырчак киезләренә бер-бер нәрсә булмаганмы, алар Турыкайның [атның] аркасын сугарлык түгелме...* А.Расих. *Атлар әле камыт, әле ыңгырчак сугудан җәфаланды.* В.Имамов

17) Гадәттәгедән көчлерәк тибү, кагу (йөрәк, пульс тур.). *[Габдрахманның] Йөрәгенең сугуы да ялгышып китеп, барган җиреннән хәле бетеп туктый торган була.* З.Зәйнуллин

18) Тиеп, бәреп, нәрсәне дә булса зарарлау, зыян салу (яшен тур.). *Уралдагы кебек көчле яшеннәр беркайда юктыр: кызып китеп, агачларны сугып яндырды, үзе яндырды, үзе сүндерде.* З.Кадыйрова. *Әллә нәрсәләрне яшен суга.* К.Җәмит

19) Үсемлекләрне, игеннәрне күпләп зарарлау (кырау, боз һ.б.ш. тур.). *[Вахап:] Әүхәдинең кызыл бозавы мөгрәмәсен төн буе, ашлыкны боз сукмасын, авылда ут чыкмасын, авызымда утыз теш, исән булсын, төшмәсен, кырылмасын, пешмәсен, эш, пеш!* Ә.Фәйзи. *Аның үзәге кырау суккан бәрәңге чәчкәсе сыман кап-кара иде.* А.Хәлим

20) Организмга тискәре тәэсир итү, зарар бирү, чирләтү. *Чыннан да, аның гәүдәсенең ярты ягын паралич суккан: сул кулы һәм уң аягы йөрми.* В.Нуруллин. *Тышта бик эссе булгач, кояш сукты бугай дип, әбисе өйрәткәндәй, яулык астына әрекмән яфрагы салып, башын кысып яулык белән бәйләде [Фатыйма].* З.Кадыйрова

21) *сөйл.* Уйнау (өстәл уеннарын һәм кайбер хәрәкәтле уеннарны). *Фойеда дүрт егет, авызларына папирос кабып, бильярд сугып ята.* Х.Сарьян. *Тәмәке*

*тарту, аракы эчү, кәрт сугу ише нәрсәләр без яшь чагында әле модага кереп җитмәгән иде.* К.Миңлебаев. *Кәшәкә сугучы малайлар [урамда уйный иде].* А.Гыйләҗев

22) *күч.* Ышанулар буенча, нинди дә булса гайре табигый көчләр кешегә бәла-каза, бәхетсезлек, чир җибәрү, зыян китерү. *Каһәр суксын дөньясын, сугыш башлаучы явызларның муенналары астына килсен!* М.Мәһдиев. *Килешерлек булсын өчен, Килешелеп торсын өчен, Сарыга буядылар, Кызларды дөньяларым... Нәләт суксын!* Ф.Яхин

23) *күч.* Нәрсәне дә булса бик тиз һәм җиңел генә ясап, эшләп чыгару. *Приборлар төзүнең әлифбасын да юньләп белмәгән йөзләп эшче һәм бер-ике инженер, беренче монометрларны әзерләп, ничек куанганнар иде! Ә хәзер «Теплоконтроль» заводы көненә меңнәрчә приборны сугып кына тора.* Азат хатын

24) *күч.* Җиңел, җайлы гына эшләп алу, табу, булдыру. *[Фотограф:] Фотографның төшеме мин хыялланганча түгел. Казан тирәсендә минем коллегалар көненә иллешәрне сугалар.* Г.Мөхәммәтшин

25) *күч.* Күңелгә, хисләргә бик авыр тәэсир итү. *Моннан да ямьсез, күңел өшеткеч, психикага суга торган сүзнең булуы мөмкинме?* Ф.Хөсни. *Дүрт ел мәдрәсәдә укып, мин күпне беләм инде, дип йөргән Габдулланың горурлыгына китереп сукты бу.* Ә.Фәйзи

26) *күч.* Тискәре нәтиҗәгә китерү, начар тәэсир итү (төрле хәлләр-шартлар һ.б.ш. тур.). *Эшсезлек негрларга тагын да катырак суга.* Ватаным Татарстан. *Эшләр киеренке, ашыгып башкарылды, җитмәсә, төзелеш эшләре кышка каршы башланды, боларның барысы да үзен сиздерде: сыйфатка сукты.* Минзәлә

27) *күч.* Тәвәккәлләп сатып алу яки ничек тә булса килешеп, уртак тел табып, тиз арада үзеңнеке итү. *[Бай – икенче бер сәүдәгәр турында:] Минем сәүдәмә аркылы төшеп йөдәтте бит инде. Тагын мин сәүдәләгән ябаганы сугып куйган бит.* Ш.Мөхәммәдев. *Маһруй белән Гөлйөземне икебез икесен сугып алыйк та Сөнгать белән Гатауны төпсез тагаракка утыртыйк.* М.Фәйзи

28) *күч.* Оештыру, кору, алып бару (әңгәмә, гәп). *Халыкның бер бүлеге, сәкегә кырын төшкән хәлдә, төрле баптан гәп сугарга тотындылар.* Г.Ибраһимов. *Агайлар, тәмәке көйрәтә-көйрәтә, шул көннәрнең вакыйгаларына бәйләп, Зөһрә йолдыз турында әңгәмә сугалар.* Г.Минский

29) *күч.* Турыдан, бик кискен итеп яки, киресенчә, кинаяләп сөйләү, әйтү. *– Берәү дә гаепле түгел, ә буровойлар бораусыз! Шушымы инде җитәкчелек? – Әнә кая китереп сукты Мансур. Ә дөрес әйтә бит.* Г.Иделле

30) *күч.* Талымсызланып һәм тиз-тиз ашау. *Получка алган көннәрдә иптәшләре белән берәр яртыны алып кайтып сугалар иде [ямщиклар].* М.Гали. *Икмәк кисәкләрен тәмле итеп суга башладылар [малайлар].* Ф.Кәрим

31) *күч. гади с.* Урлау, чәлдерү. *Әстәгъфирулла, теге сервизның бер чынаягы җитми ләса! --- Тагын нәрсәләрне суктылар икән?* Д.Булатова

◊ **Сукса тимер өзәрлек (өзәрдәй)** Бик көчле, таза; типсә тимер өзәрлек. *Аның сукса тимер өзәрлек йодрыгы берсе арты берсе әни аркасына төшә башлады.* А.Алиш

**Суга башлау** Сугарга керешү. *Икмәк кисәкләрен тәмле итеп суга башладылар [малайлар].* Ф.Кәрим. *Дәртле аһәңнәрен яңгыратып, Кремль курантлары җиһанга Яңа ел килүен хәбәр итеп суга башлады.* Х.Бәдигый

**Суга бирү** Бернигә карамый сугу. *Рельс кисәге елады да елады, аның саен карт селтәбрәк суга бирде.* М.Мәһдиев

**Суга тору** Алдан, башка эш-гамәл башланмас борын яки шуның барышында сугу

**Суга төшү** Тагын да ныграк сугу

**Сугып алу** Тиз арада сугу; бер мәртәбә сугу. *– Бетте! – Алексей Лукич учы белән өстәлгә сугып алды.* Г.Әпсәләмов. *Тәлгать аның иңсәсенә җиңелчә генә сугып алды да Фәриткә таба борылды ---.* Ә.Дусайлы

**Сугып бару** Рәттән барысына яки барысын да сугу

**Сугып бетерү** Сугуны тәмамлау; барысын да сугу. *Язгы чәчү башланганчы, ничек тә сугып бетерергә кирәк ич безгә игенне!* В.Нуруллин

**Сугып җибәрү** Кинәт сугу. *Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Нурми аның иңенә сугып җибәрде.* Д.Гарифуллин

**Сугып йөрү** Сугу белән мәшгуль булу; шактый вакыттан бирле сугу эше белән шөгыльләнү. *Ишегалдыннан көрәк, балта ише нәрсәләр югалгалады. Бигрәк тә Ләсел малайлары усал иде: суккалап йөриләр.* Э.Касыймов

**Сугып кую** Бер тапкыр сугу; алдан сугып әзерләү. *Ике өчпочмакны сугып куйдым инде мин.* Г.Каюмов. *– Ват бит какой дило! – диде, бүтән сүз табалмагач, шапылдатып, сакаллы агайның иңбашына сугып куйды.* Г.Бәширов

**Сугып тору** Әле, хәзер сугу; даими яки әледән-әле сугу. *Һәр яңалыкны барыннан да алда ишетә торган Зәйнәп апа – безнең коридордагы карчык: «Карале бу Хәятне, бу тиклем дә шайтан камчысы булыр икән!» – дип, үзенең ботына сугып торды.* Т.Нурмөхәммәтов

**Сугып чыгу** Барысына да сугу. *Молекулаларында бензол боҗрасына берничә углеводород радикалы тоташкан матдәләрне исемләү өчен, формуладагы углерод атомнарына номер сугып чыгалар ---.* Органик химия

**СУГЫЛУ** *ф.*1) *төш. юн. к.* **сугу**

2) Бик нык орынып китү, каты итеп бәрелү. *Башым бик нык сугылды [таудан тәгәрәгәндә], кулым сынган, ахрысы.* Ш.Камал. *Диңгез дулкыннары берббер артлы Текә ярга килеп сугылалар.* Ә.Ерикәй

3) Ыргылу, талпыну. *Кинәт әрәмәлектә шау-шу купты: атлар өркеп бер якка сугылдылар, кешеләр куркып кычкырып җибәрделәр.* А.Шамов. *Мин ары сугылып, бире сугылып, Лотфулланың кулыннан ычкынырга омтылам.* Ә.Айдар

4) Юнәлешне үзгәртү, борылу; төп юлдан чыгып, ян юл белән китү. *Башта без чокыр эчләп бара торган зур юл белән киттек һәм, байтак барганнан соң гына, юлдан сулга, агачлар арасына сугылдык.* С.Җәлал

5) Юл уңаеннан гына керү, кереп чыгу. *Ара ике генә чакрым бит, их, Кимегә дә сугылган булса шунда.*

А.Арсланов. --- *тиктомалдан гына «Балалар дөньясы» кибетенә сугылып чыгарга булды.* Л.Лерон

6) Кемгә дә булса берәр сорау, теләк, гозер белән мөрәҗәгать итү. *Алай да син минем кызның йоласын беләсең микән? Ул үзенең теленә торырдай чичән егеткә генә чыгам дип ант иткән бит. Монда күпләр сугылып карады.* Н.Исәнбәт

**СУГЫМ** *и.* **1.** 1) Ит өчен махсус суела торган йорт хайваны; итлек. *Маладис, улым, расхутлар бик күп, чуваштан сугымга ат та аласы бар...* Д.Гыйсметдин. *Ир-ат бар өйдә сугым суйдылар. Шәмсетдин агай елдагыча быел да елкы чалды. Күршедәге ятим Чынбикә әбинең сугымы юк.* Ш.Янбаев

2) Ит өчен хайван сую эше. *Байгузиннар унике каз, бер тана, бер иләмсез зур дуңгыз һәм, өч хуҗа берләшеп, бер яшь ат суйдылар. --- Бу – һәр көзен кабатлана торган сугым.* Ә.Еники. *Сугымга чыгарылган мал диярсең, һәммәсе дә сүзсез буйсындылар.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* Иткә сую өчен атап куелган, шуңа дип асралган. *Алар авылдан сугым мал куып килгәннәр икән.* Р.Вәлиев

**СУГЫМЛЫК** *и.* 1) Сугымга дип асралган, сатып алынган мал. *Гыймран агайның сугымлык сатып алуында мин безнең бригада егетләренең берсендә дә булмаган кәсепчелек һәм сәүдәгәрләр осталыгы күрдем.* Г.Ахунов

2) *к.* **сугымханә**. *Ә сез аларны сугымлыкка китереп, тереләй дигәндәй тиресен салдырып, зур гуман акт эшлисезме?* Р.Фәйзуллин

**СУГЫМХАНӘ** *и.* Сугымга дигән терлекне сую һәм түшкәләрне эшкәртү өчен махсус корылма. *Казаннан артсыз чаналы извозчиклар – барабызлар, Семипалат һәм Оренбурдагы сугымханәләрдән терлек суючылар; ярминкәләрдә, татар сәүдәгәрләрендә төрле яллы хезмәттә кыш уздырган көнлекчеләр, Русиянең вак һәм эре шәһәрләрендә я дворник, я кучер, ат караучы, я каравылчы булып эшләгән крәстиян агайлар кайтып кердә.* М.Галәү

**СУГЫМЧЫ** *и.* Сугым суючы, мал сую эше белән шөгыльләнүче кеше. *Сугымчылар пычак кайрады, аксакаллар, Утташ кам җитәкчелегендә, изге түгәрәктә мәш килделәр.* Н.Фәттах. *Бил каешына кыстырган пычак та картайган сугымчы кулыннан төшеп калган сыман.* В.Имамов

**СУГЫШ** *и.* 1) Сугу (*1 мәгъ.*) хәрәкәте; сугу рәвеше. *Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың.* А.Шамов

2) Бер-береңә сугу, кыйнаш. *Урамнарда гауга, сугыш, кеше кыйнаш кебек күренешләргә тап булмадым.* Р.Батулла. *Берәрсенең борыны яки ияге дә җимерелсә тагын, театр да килми торган авылыбыз өчен ай буе көләкөлә сөйләрлек, күңел ачарлык тамаша итеп кабул иткән булыр идек ул сугышны.* Ф.Баттал

3) Төрле дәүләтләр, илләр, армияләр һ.б.ш. арасындагы кораллы көрәш. *Сугыш беткәнгә өч-дүрт ел узган булса да, рәтле тормыш күргән юк әле безнең.* Р.Сәгъди

4) Шул көрәшнең аерым бер бәрелеше. *Кичә каты сугыш булды. Немецларны тозлап-борычлап пешердек.* Г.Кутуй. *Әмма Рига өчен сугышта немец шулчаклы нык каршылык күрсәтте, хәтта күпне күргән сугышчыларның да моңа исләре китте.* Х.Камалов

◊ **Сугыш алласы** Туп, пушка һ.б.ш. артиллерия коралы. *Менә мин Мәскәү вокзалы янында утырам. Каршыда кирпеч ватыклары. Димәк, монда да сугыш алласы төкергән.* Г.Бәширов. **Сугыш кыры** Сугыш бара торган территория; фронт. *Кырык икенче елның рәхимсез салкын көннәрендә аның Шәйдулладан олырак улы сугыш кырында үлеп калды.* М.Мәһдиев. *Безнең Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Фатих Кәрим, Нәби Дәүли һәм тагын бик күп әдипләребез исә канкойгыч сугыш кырына юл тота.* Р.Низамиев. **Сугыш мәйданы** *к.* **сугыш кыры**. **Сугыш төтенен иснәү** Фронтта булу, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашу. *Мостафа һәм аның шикелле үк сугыш төтенен иснәп кайткан берничә солдат --- эшче дружинникларны Бакалтай таллыгында мылтык кулланырга өйрәтәләр.* К.Нәҗми. **Сугыш уты** Сугыш куркынычы; сугыш китереп чыгарган тискәре нәтиҗәләр. *Аның сизүенчә, менә-менә сугыш утының ялкыннары дөньяны ялмап алыр төсле, дөньяга сугыш уты кабар, сугышларның янгыны кешеләрнең бөтен изге хыялларын көлгә әйләндерер төсле.* Ә.Мәхмүдов. *Ягъфәр белән Хәтимәнең мәхәббәт чәчәге суык тигәннән түгел, ә сугыш уты ялкыныннан көйгән, көл-күмергә әйләнгән.* З.Зәйнуллин. **Сугыш уты кабызу** Сугыш башлау, аны китереп чыгару, аңа сәбәпче булу. *Сугыш уты кабызырга ирек бирмәбез.* Жыр. *Америка белән Англия реакционерлары яңа сугыш уты кабызу турында ничек шаулыйлар.* Г.Әпсәләмов. **Сугыш уты кабызучы** Сугышны пропагандалаучы һәм шуны башлаучы; агрессор. *Баштагы чирек сәгатьне халыкара хәлләргә багышлады, салкын сугыш уты кабызучы Черчилльне сүкте.* А.Гыйләҗев. *Сугыш уты кабызучы тын алмасын, Сугышларны башлар өчен көн калмасын.* Ш.Галиев. **Сугыш уты кабыну** Сугыш, сугышчан хәрәкәтләр башлану. *Көнбатыш Европада сугыш уты кабына.* С.Поварисов. **Сугыш чукмары** 1) Сугышырга, ызгышырга гына торучы; күп сугышучы, ызгышучы. *Жибәр! Жибәр, диләр сиңа! Сугыш чукмары! Синнән башка да юлны беләм.* Ә.Хәсәнов. *– Әнә сугыш чукмары кайтып бара! – Әнә тәрәзә ватучы!* А.Гыйләҗев; 2) Сугыш башлаучы як, агрессор. *Сугыш чукмарлары, акырынмагыз. Без бит курка торган ил түгел.* Ә.Ерикәй

**СУГЫШТАШ** *и. сир.* Кем белән дә булса фронтта, сугышта бергә булган кеше. *Тагын менә нәрсә: андагы хәлләр, сугышташ иптәшләрең турында син бушрак вакытларда мөмкин кадәр тулырак язарга тырыш.* С.Сабиров

**СУГЫШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сугышу** (*2–4 мәгъ.*). *Габдулланы күрү белән, алар аны үзләре белән ияртеп Миркәйләр тыкрыгындагы әлеге бүрәнәләр янына алып килделәр, һәм бирелә «күкәй сугыштыру» башланды.* Ә.Фәйзи

2) Кызык, тамаша булсын өчен көрәштерү, талаштыру; бер-берсенә өстерү (кош, вак җәнлек, бөҗәк һ.б.ш.ларны).

*Имештер, аларда [Урта Азия халыкларында] тик шул гына бар: әтәч, бүдәнә сугыштыру, нәшә тарту, әфьюн салу!..* З.Бәшири. *Миңлебай унҗиде яшенә кадәр мәдрәсәдә укыса да, атага бер булганлык сәбәпле, иркә булып, укуга күп ихлас куймаенча, күгәрчен очыру, әтәч сугыштыру шикелле уеннар берлә мәшгуль булды.* Ш.Мөхәммәдев

3) *күч.* Котырту, араларын бозу, бәрелештерү. *Аларның нигезендә дә һаман шул, большевиклар яраткан, кешене кешегә каршы кую, кешене кеше белән сугыштыру принцибы ята иде.* Ә.Еники

**Сугыштыра башлау** Сугыштырырга тотыну. *Болай эшләсәк, озакламый завод белән шәһәрне сугыштыра башлыйбыз.* Р.Вәлиев

**Сугыштыра бирү** Бернигә карамый сугыштыру

**Сугыштыра язу** Аздан гына сугыштырмый калу

**Сугыштырып бетерү** Үзара барысын да тәмам, бик нык сугыштыру

**Сугыштырып тору** Даими, гел яки әледән-әле сугыштыру; хәзер сугыштыру

**СУГЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **сугу**

2) Бер-береңбелән кыйнашу. *Я Аллам! Нинди көн соң бүген? Тегендә сугышалар, монда елыйлар.* Акмулла. *Ул, сугышканда, үзе сукса да, үзенә суксалар да, әтәч шикелле сикереп-сикереп куя иде.* Г.Гобәй. *Кырынып, чистарынып мәктәпкә барып кергәндә, озын тәнәфес җиткән, коридорда ду килеп уйнайлар, сугышалар, укытучылар бүлмәсендә шыгрым тулы халык иде.* М.Мәһдиев

3) Бер-беренә карата сугыш (*3 мәгъ.*) хәлендә булу (дәүләтләр тур.)

4) Корал белән көрәшү (армияләр, сугышчылар һ.б.ш. тур.). *Кайталмады өйгә зур улым: Сугышып үлде, бәгърем, күз нурым.* М.Җәлил. *Кол булып яшәүгә караганда сугышып үлү артыграк.* А.Шамов

5) *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешү өчен, бик нык тырышу, көрәшү. *Сугыш елларында әрсезләнеп киткән әрембилчәннәр, шайтан таяклары белән куллар канланганчы, тырнаклар купканчы сугыша-сугыша саклап калган, ниһаять, бөртекләп, кадерләп җыйган тары бит ул.* А.Гыйләҗев. *--- полягы да, шведы да, литвалысы да үз бәйсезлекләре өчен пычакка пычак килеп сугышалар.* Ф.Бәйрәмова

**Сугыша башлау** Сугышырга тотыну; сугышның башлангыч ноктасында булу. *Колония бүлүдә ызгышып китеп, империалистлар үзара сугыша башладылар.* В.Юныс

**Сугыша бирү** Бернигә карамый сугышу

**Сугышып йөрү** Шактый вакыт сугышу. *Фронтларда сугышып йөрдем мин.* Б.Рәхмәт

**Сугышып тору** Әле сугышу; даими яки әледән-әле сугышу

**СУГЫШЧАН** *с.* 1) Сугыш (*4 мәгъ.*) белән бәйле. *Менә бүген безнең алдыбызга кичектерелми үтәргә куелган аеруча мөһим сугышчан приказ шушы.* Ф.Кәрим. *Алар аз санлы кешеләрдән сугышчан группалар төзегәннәр.* Г.Әпсәләмов

2) Сугышка сәләтле, сугышка әзер. *Сугышчан гаскәр*

3) Кыю, тәвәккәл. *Ассирия осталары үзләренең әсәрләрендә һәрвакыт таза гәүдәле сугышчан ирләрне генә гәүдәләндерергә тырышканнар.* Г.Гали

4) Сугышка осталыкны, әзерлекне һ.б.ш. белдерә торган. *Сугышчан антын --- җиренә җиткерде ул.* С.Хәким. *Дошманны җиңү теләге көннән-көн көчәя, кыза бара дип, автор халыкта сугышчан рух, патриотик хисләрнең сүнмәве турында сөйли.* Ә.Алиева

5) Бик актуаль, тәэсир көче зур булган (лозунг, мәкалә, нотык һ.б.ш. тур.). *Алгы сызыкта гына кирәкле геройларны күрергә, материал табарга, сугыш хәлләрен күзәтергә мөмкин. Шунсыз газетаны оператив һәм сугышчан итеп булмый.* М.Җәлил. *Ул речен барыбыз өчен дә сугышчан лозунг булып әверелгән сүз белән тәмамлады.* К.Нәҗми

**СУГЫШЧАНЛЫК** *и.* 1) Сугыш (*3 мәгъ.*) алып баруга сәләтлелек, сугышка (*3 мәгъ.*) әзер булу дәрәҗәсе; *русчасы*: **боеспособность**. *Инспектор легионерларның сугышчанлык ягыннан бигрәк сәяси якларын [тикшерде].* Ш.Усманов

2) Сугышка хирыслык, тиз сугышып китүчәнлек; *русчасы:* **воинственность.** *--- һуннар, скифлар, төркиләр яки татарлар турында Европада да, Ерак Көнчыгышта да бер үк төрле итеп сөйләгәннәр һәм язганнар: шул ук күчмә тормыш, өсте ябык арбалар, күпләп мал тоту һәм сугышчанлык ---.* И.Хуҗин

3) Батырлык, кыюлык. *Шул ярыш аркылы массага яңа – күмәкчелек, эшкә бирелгәнлек, дәртлелек, батырлык, киләчәккә ышанучылык, сугышчанлык, эшчәнлек тойгылары бирелсен. Менә безнең әдәби фронттагы төп бурыч.* М.Җәлил

4) *күч.* Нәтиҗәлелек, үтемлелек, тәэсир көче; куелган бурычларны үтәүгә сәләтлелек. *Автор вакыйгалар үзәгендә булып, үзен шунда катнашучы итеп түгел, ә читтән күзәтеп, бөтенесен бик тәртипле теркәп баручы кебек тәэсир калдыра. Мондый алым очеркларның сугышчанлык сыйфатын киметә.* Г.Иделле

**СУГЫШЧЫ** *и.* **1.** 1) Солдат, рядовой гаскәри. *Бер төркем сугышчылар белән Урманов аларны ярга кадәр озата барды.* Г.Әпсәләмов. *Каты сугышлардан соң капитан Фәтхетдинов тугыз сугышчысы белән --- дошман тылына бәреп керә.* С.Шакир

2) Гомумән сугышта (*3 мәгъ.*) катнашучы кеше, сугышучы. *Яралы сугышчыны саклап, Суфия ханым дошман боҗрасы эчендә калды.* Г.Әпсәләмов. *Хәмит һәр сугышта үзен оста сугышчы, Ватанның батыр сугышчысы итеп танытты.* Р.Ишморат

**2.** *с. мәгъ.* Еш сугыша (*2 мәгъ.*) торган, сугышу гадәте булган, сугышучан. *Алар – бик сугышчы халык.* Г.Камал. *– Авылда чакта зерә сугышчы малай идем, – диде ул елмаеп. – Безне, сугышчы Аю Гатаулла малайлары, диләр иде, ә хәзер мин җил иссә дә егылырга торам.* Г.Әпсәләмов

**СУД** *и. рус* 1) Дәүләтнең граждannар арасындагы низаг, бәхәс һәм җинаять эшләрен хәл итә торган хөкем органы; мәхкәмә. *Милиция, икесен дә [сугышучыларны] эләктереп, эшләрен судка бирә. Суд штраф сала.* Ә.Айдар. *Прокуратура, суд, эчке эшләр бүлеге*

*хезмәте турында сөйләгәндә, ничектер күңелгә суык йөгерә, күз яше, кан күз алдына килеп баса.* Маяк

2) Нинди дә булса коллективта, төркемдә җәмәгать тәртибен бозуга бәйле һ.б.ш. эшләрне хәл итү өчен, шул коллектив әгъзаларыннан сайлап куелган җәмәгать органы. *Мин сине барыбер ячейка судына бирәчәкмен.* Г.Ибраһимов

3) *җый. и.* Суд утырышында катнашучы судьялар. *[Судья:] Сораулар бетте, суд киңәшкә керә, ярты сәгатьтән хөкем карары игълан ителер.* М.Гали. *Тыныч кына торыгыз, суд килә!* К.Нәҗми. *Залда һаман түземсезлек арта, ә суд дәшми.* З.Мансур

4) Суд органнарының нинди дә булса бер эшне тикшерү утырышы. *Киләсе атнага безнең авылда Шәйхетдиновларга күргәзмә суд була.* Т.Гыйззәт. *Димәк, әле иптәшләр суды булачак.* А.Алиш. *1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була.* Гасырлар авазы

◊ **Суд алдына басу** Нинди дә булса җинаятьтә гаепләнеп, суд җаваплылыгына тартылу. *Карт башым белән суд алдына барып басмам, юк.* А.Шамов. **Судка бирү** Суд хөкеменә тапшыру, рәсми рәвештә мөрәҗәгать итеп, судның тикшерүен һәм хөкем чыгаруын сорау; суд җаваплылыгына тарту. *Крестьяннар, үзләрен хаклы санап, эшне судка биргәннәр.* И.Гази. *Губернатор аны [Г.Камалны] судка бирүне таләп итә.* М.Хәсәнов. **Судка кую** *к.* **судка бирү**. *[Хурлаган] өчен мин аның эшен судка куям.* Р.Ишморат. **Суд каршысына басу** *к.* **суд алдына басу**. *Шуннан гына сатып алган булсаң, суд каршысына басмаган булыр идең...* Ф.Баттал. **Суд эскәмиясенә утыру** *к.* **суд алдына басу**. *Ул иртәгә суд эскәмиясенә утырачак.* Н.Фәттах. **Суд эскәмиясенә эләгү** *к.* **суд алдына басу**. *Караклар суд эскәмиясенә эләккәннәр.* Ватаным Татарстан

**СУДАК** *и. рус зоол.* Алабуга балыклар семьялыгыннан төче суларда һәм диңгездә яши торган кыйммәтле промысел балыгы; сыла. *Торпеда кебек җитез судакларын кармакка каптырып караган кеше Ык буйларын оныта аламы?!* М.Шабай. *Хәзер күбрәк кармакка корбан балыгы эләгә, кайбер урыннарда судак та чиртә икән.* Авыл офыклары

**СУДЛАШУ** *ф.* Нинди дә булса дәгъвалы эшне суд аша хәл итү. *Халык судлаша-судлаша бөлеп бетте.* Г.Исхакый. *[Рамай:] Сабир белән судлашып, бернәрсәсез калдым.* Т.Гыйззәт

**Судлаша башлау** Судлашырга тотыну. *Бу атнада, нотариусны чакыртып, завещаниесен дә алдырырга иде бит әле, әллә үлеп китәр, шулкадәр дөнья, теге карчыгы судлаша башласа?!* Х.Мөдәррисова

**Судлашып алу** Бер ара судлашу

**Судлашып бетү** Эш судлашуга кадәр барып җитү. *Төрле низагларга кереп, якыннары белән тәмам ызгышып, судлашып бетәләр...* Й.Дәүләтшин

**Судлашып йөрү** Судлашу белән мәшгуль булу. *Сукрана әти. Ә үзе ил-көн эчендә тавыш кубарып, судлашып йөрергә дә уңайсызлана.* Ш.Маннур. *Хисмәт кода судлашып йөрмәде.* М.Мәһдиев. *Табибларның гаебе барлыгын чамаласа да, ул прокуратурага язып, судлашып йөрергә җыенмый.* Г.Сафин

**Судлашып тору** Даими яки әледән-әле судлашу; судлашу хәлендә булу

**СУ́ДНО** *и. рус* 1) *махс.* Төрле зурлыктагы һәм төрле максатларда кулланыла торган йөзмә корылмаларның гомуми атамасы; башлыча пассажир һәм йөк ташу чарасы. *Портка барып кергәндә һәм чыгып киткәндә, тар бугазлардан узганда, капитан һәрвакытта да судно белән идарә итүне үз кулына ала.* М.Мәһдиев. *Минем әнинең абыйсы балык тоту судносында капитан булып чыкты.*Э.Яһудин

2) *сөйл.* Урында яткан авыруларга бирелә торган тәрәт савыты. *Әнвәр, сыңар аягы исән килеш, судно дип тилмерә. Палатада авыр яралылар булмагач, нянялар да ерак йөри.* Х.Камалов. *Син аңарга су алып керергә кушасың, ә ул судно күтәреп керә, син тастымалыңны алыштырырга сорыйсың, ул астыңнан җәймәңне тарта башлый.* Ф.Яруллин

**СУ́ДНОЧЫ** *и. махс.* Суднолар төзү, ремонтлау эшендә эшләүче кеше. *Чистай судночылары*

**СУ́ДНОЧЫЛЫК** *и. махс.* Су юлларыннан суднолар йөртү эше; шул юл белән пассажирлар һәм йөк ташу. *Агыйдел төбәге су юллары һәм судночылык начальнигы Станислав Большаков сүзләренә караганда, узган елда Башкортстанда 3,5 миллион тонна йөк ташылган.* Ә.Шәрәфетдинова. *«Татфлот» судночылык компаниясе дүртенче сентябрьдән көзге эш режимына күчкән.* Татарстан яшьләре

**СУДЬЯ** *и. рус* 1) Судка (*1 мәгъ.*) куелган эшләрне закон нигезендә хәл итеп хөкем чыгаручы белгеч, суд хезмәткәре; хаким. – *Ул исерек иде, – дип ышанып әйткән медицина хезмәткәреннән судья дәлил сорады.* Э.Фатыйхова

2) Спорт ярышларында кагыйдәләрнең һәм шартларының үтәлешен күзәтеп, бәхәсләрне хәл итеп торучы белгеч; арбитр. *Ярышның баш судьясы – атаклы спортчы, грек-рим көрәше буенча Олимпия уеннары призёры, дөнья чемпионы Фәрхәт Мостафин (Олимпия чемпионы Алия Мостафинаның әтисе) хәрәмгә урын калдырмады.* Туган як. – *Җәйге каникулларның бәйгедән башланып китүенә аеруча әтиәниләр шатланадыр, – диде ярышның баш судьясы, оештыручы Илһам Хантимер улы.* Кызыл таң

**СУДЬЯЛЫК** *и.* Судья белгечлеге, хезмәте һәм вазифасы. *7 нче мәктәптән Захар Семёнов бик оста судьялык итте.* Заман сулышы

**СУЕЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сую**. *--- әллә никадәр миллион хайван суелып, үлеп, һәлак булып беткәндер.* Г.Исхакый. *--- аңа кичтән суелып, туналып, туралып, үлчәнеп, ниһаять, алып китеп, каядыр җыйналып куелган берәр сыерның --- пешерелгән кайнар итен, җылы сөякләрен иплән куя торган иде.* Ә.Гаффар. *Сарыклар суела, казаннар асыла, пылау пешерелә.* Г.Газиз

2) *кайт. юн.* Үз-үзеңә кул салу, үзеңне сую. *Ни эшлисең бит, аның артыннан үзең суелып булмый инде.* Т.Гыйззәт. *Гафият дөрес әйтә: җир шундый кирәк, хет суел.* И.Гази

**Суела башлау** Суелырга тотыну

**Суела тору** Һаман саен ныграк суелу

**Суелып бетү** Тәмам, бик нык суелу. *Комбатның йөзе тырналып, суелып беткән.* Х.Камалов. *Ике авыл арасын*

*таптап, аякларым суелып бетте, табан асларым уттай яна*. Д.Салихов

**Суелып төшү** *к.* **суелып чыгу**. *Кулларын артка каерып бәйләгәннәр, нечкә иске бишмәте телгәләнгән, якалары суелып төшкән, кан катыш балчыкка пычранган коточкыч йөзе һәм зур гәүдәсе белән Җолкынбай ята*. Г.Ибраһимов

**Суелып чыгу** Бөтенләйгә суелу. *Өйгә кайтыр вакыт җиткәч исләренә килсәләр, һәммәсенең тиреләре суелып чыккан: кып-кызыл кан!* Ә.Баян. --- *уткән атнада бәлеш пешергәндә пешкән кулы, егет каты итеп тотканга, суелып ук чыкты*. Ә.Шакирҗанова

**СУЕР** *и.* Кыргавыл кошлар семьялыгының көртлекләр ассемьялыгыннан урманда яши торган эре кош; урман тавыгы; *русчасы*: **глухарь**. *Аның янына суер килеп чыкты.* К.Тәхау. *Мин моны үземнең акылым белән төшенеп алдым да, мәхәббәт уеннары вакытында ике көпшәдән берьюлы атылган суер шикелле тынып калдым.* Ә.Мушинский

**СУЕШ** *и.* Күпләп үтереш (суеп, чәнчеп үтерү тур.). *Менә сиңа бер гасыр эчендә сигез суеш.* М.Галиев. *Кайдадыр кырылыш, суеш бара*. Р.Батулла

**СУЗАН** *с.* 1) Озын, чандыр гәүдәле. *Чегәнне хәтерләткән карасу озынча йөзле, зур авызлы, сузан буйлы Ирина Моисеевна.* Х.Камалов. *Ул буйлы булса да, кайбер кинәт үсеп киткән кызлар кебек котсыз сузан, юка кыз түгел әле.* А.Гыйләҗев

2) Гадәттәгедән озынрак һәм килешсезрәк; тар һәм озын. *Сузан муеннарын әрле-бирле йөрткән гигант краннарга күптән инде игътибар иткән идем.* А.Расих

**СУЗАНЛАНУ** *ф.* Сузанга әйләнү

**Сузанлана бару** Акрынлап сузанлану

**СУЗАЮ** *ф.* 1) *диал.* Озынаю; сузылу. --- *төз лапасның юан, таза өрлегенә сүс дилбегә бәйләп, шәп бер гәүдә асылынган, ул гәүдә сузайган, сары ботинкалар җиргә тиеп кенә калмаган, аяклар тездән бөгелгән ---*. М.Мәһдиев

2) Тирә-яктагы нәрсәләрдән озынрак, биегрәк булып, күзгә ташланып тору. *Анда сугышка кадәр йөз илле йорт булган, ә хәзер бары бер кечкенә генә йорт сузаеп тора: каһәр төшкән немецлар бөтенесен яндырганнар*. Г.Кутуй. *Габитов таныш урманнарга, кызыл маңгайлы таныш тауларга, сузаеп басып торган буровойларга карап кайтты*. И.Гази

3) Тырпаю. *Гомәр Фәлинәне озата кайткач, былтыргы утын агачларының күккә сузаеп торган очларына карады*. Гәрәй Рәхим

4) *күч.* Кирәксез яки тиешсез урында басып тору. *Калды Һашимов кыз янында берүзе сузаеп*. Р.Зәйдулла

**Сузаеп калу** Берәр тәэсирдән сузайган хәлгә килү. *Гаделшинның йөзе сузаеп калды, ләкин елтыр кәгазьне бирмичә булдыра алмый иде инде ул: кулы куелган, мөһер сугылган!* Р.Зәйдулла

**Сузаеп китү** Бер ара күзгә күренеп, сизелерлек сузаю

**Сузаеп тору** Даими сузайган хәлдә булу; сузайган булып күренү. *Бөтен төбәккә бер булып, безнең чиркәү гөмбәзе генә күккә сузаеп тора иде.* Гәрәй Рәхим

**Сузая башлау** Сузаерга тотыну

**СУЗУ** *ф.* 1) Нык тартып, киереп һ.б.ш. юллар белән озынайту. *Бик каты сузсаң, җеп тә өзелә бит: без дә чыдамадык*. Г.Ибраһимов

2) Төз рәвешкә китерү, турайту. *Астыңда нибары юка палас кына я бишмәт чабуы гына икәнлеге дә, урын тарлыктан аякларыңны сузып, әлиф ятуың да онытыла.* Г.Бәширов. *Купшы офицер күкрәген киереп, кулларын бот буена сузып, кызу-кызу гына нидер әйтте*. Ә.Еники

3) Кулны, аякны яки гәүдәнең берәр өлешен берәр якка таба бору, юнәлтү. *Хәтта колхоз рәисенең артын сузыбрак атлавы да, авыл советы рәисенең ялтырап торган пеләш баш түбәсе дә аермачык «бу – без!» дип торалар.* Н.Көбәш. *Ышанасыңмы: ул син идең... һәм син миңа кулларыңны суздың...* А.Тимергалин

4) Алга таба җибәрү, алга чыгару, юнәлтү (баш, борын, муен тур.). *Хәлим тиз генә мунча ишеге төбенә килде. Колагын бәрәңге бакчасы ягына сузып тыңлап торды да шунда мунча өйалдына керде*. Г.Гобәй. *Абыйның иңбашы аркылы борынымны сузып, шул сузләрнең чыккан урыннарын эзләргә тотындым.* Г.Бәширов. *Озын муеннарын сузып, саф-саф булып тезелешеп, казлар кайтып киләләр.* А.Әхмәт

5) Кулдагы берәр нәрсәне кемгә дә булса тәкъдим итеп сону, аңа юнәлтү; бирү хәрәкәте ясау. *Зәйнәп тиз генә кулындагы төргәкне Газизгә суза да, үзе чыгып китмәкче була.* Ф.Әмирхан. *Кыз Сәфәргә сөлгене сузды һәм елмаеп нәрсәдер әйтте.* Ә.Фәйзи. *Кайсы коча, кайсы кулны кыса, Чәчәк суза кайсы кулыма*. Ә.Исхак

6) Билгеле бер юнәлештә урнаштыру, үткәрү, тезү, кору (юл, элемтә һ.б.ш. тур.). *Әйләнә дә дәшә Басыйрга ул: – Ике ярны ничек ялгадың, Ничек күпер суздың?!* Р.Әхмәтҗанов. *Батальон штабын шул йортларның берсенә күчерделәр. Телефон суздылар.* З.Зәйнуллин. *Үрмәкүчләр ботактан ботакка җеп сузган, пәрәвез корган.* Ш.Бикчурин

7) Үтәлү-эшләнү яки тәмамлану вакытын тиешледән озаграк дәвам иттерү, озакка җибәрү. *Буржуа өчен сугышны сузу файдалы.* Ш.Камал. *Кем чәчүне җәй уртасына тикле суза?* Г.Бәширов

8) Озаграк дәвам иттерергә тырышу, озынайту. *Поль, Тукайда булмаган авыру юк, әгәр дә гомерен бераз сузу мәтлүп булса, тизрәк Петербургтан җылы якка озатырга кирәк, дип мәслихәт бирде*. К.Сәгыйд

9) Кичектерү, чигерү; тоткарлау. *Юкка сузасың. Барыбер кайчан да булса бер әйтергә кирәк булачак.* Р.Ишморат

10) Озын итеп әйтү, әкренрәк, салмаграк әйтү (аваз, сүз һ.б.ш.ларны). *– Ах, малла-ай, – дип сузды Мәрданша бабай. – Нигә мине уятмадың соң син шул чакта?..* Г.Гобәй. *Ә бераздан Мәрьям абыстайның колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп ишетелә.* Ә.Еники. *Телефон сузып-сузып ике тапкыр шалтырады.* М.Хәсәнов

11) *күч.* Матур, оста итеп башкару (гадәттә озын җыр, көй тур.). *[Солдат] авыз эченнән әллә нинди бер көй суза.* Ш.Усманов. *Ул гармун остасы түгел, гадәти генә уйный; берәр моңлырак авыл көен сайлый да шуны хәсрәтле генә итеп сузарга тотына.* Ш.Маннур

**Суза бару** Акрынлап сузу

**Суза башлау** Сузарга тотыну. *Озын-озын көйне кайгы-хәсрәт белән әкрен генә, әкрен генә суза башлыйбыз.* Г.Ибраһимов. *Теге яктан Мирхас Мөслимовка озын колга суза башлады: шуның белән атынып сикер, янәсе.* Х.Камалов

**Суза бирү** Бернигә карамастан сузу; тагын бераз сузу. --- *башын артка ташлап, тезләрем өстенә куйды да, киерелгәндәй кулларын суза биреп, башымнан кочаклап алды.* Х.Сарьян

**Суза төшү** Бераз сузу; тагын да сузу. *Йонлач башын аз гына кыйшайтып, очлы борынын тагын да суза төшеп, миңа төбәлде.* А.Хәсәнов

**Сузып алу** Аз гына сузу, бер мәртәбә сузу; тиз генә сузу. *Үзе, кытыкламакчы булып, кул-бармакларын сузып-сузып ала, ди...* Г.Гыйльманов

**Сузып бетерү** Барысын да сузу; нык сузу. *Арткы аякларын да бар җаена ыргытып бәрми, сузып бетерми сыман.* В.Имамов. *Нурулла, сары чәчкә ата башлаган кыяр сабакларын югарыга үрләтү өчен җеп сузып бетергәч, гәүдәсен турайтып, куллары белән бөеренә таянды.* Ф.Садриев

**Сузып җибәрү** Кинәт сузу; иркенләп сузу. *Рашат сәгатенә карап алды да, күзләрен йомып, нәрсәдер уйлагандай, беркадәр торды, аннары кинәт аягын сузып җибәрде.* Ф.Садриев. *Әкрәм, күңелсез хәлләрне онытып торыйк диптер инде, «Алмагачлар»ны сузып җибәрде.* Р.Сәгъди. *Менә сукыр бабай гармунын сузып җибәрде, кызчык озын, кызганыч көйгә җыр башлады ---.* Ф.Әһлиуллина

**Сузып килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә сузу. *Вәли көн саен миннән үземне аның хатыны дип халыкка белдерүемнең сәбәбен сорый. Мин «иртәгә», «иртәгә» дип сузып килдем.* Г.Кутуй

**Сузып кую** Сузылган итү; бер мәртәбә сузу; кисәк сузу. *– Ә-ә, – дип сузып куйды Мәдинә, кайсы Мортаза икәнен аңлап ---.* М.Хәсәнов. *Утыргач, протез аягын сузып куйса, галифе балагыннан түгәрәк резинасы гына түгел, ялтыр тимере дә күренә.* М.Галиев

**Сузып тору** Даими яки әледән-әле сузу; сузган хәлдә булу. *Азат озакка сузып тормый, шул кичне үк юл хәстәрен күрә.* А.Тимергалин

**СУЗЫК** *с. лингв.* Һава агымы авыз куышлыгыннан тоткарлыксыз үтү нәтиҗәсендә ясалган, акустик яктан тавыштан гына торган (шау катнашмаган – аваз тур.). *Екатерина II заманындагы рус галиме А.С. Шишков, иң әүвәлге телләр бериҗекле сүзләрдән торган, ул иҗекләр сузык авазлар булган, ди.* Н.Фәттах. *Темников сөйләшендә сузык авазлар, гомумән мишәр диалектындагы кебек үк, алгырак позициядә ясалалар ---.* Татар халык сөйләшләре

**СУЗЫЛМА** *с.* Сузыла торган; сузылу үзлеге булган

**СУЗЫЛМАЛАНУ** *ф.* Сузылмага әйләнү, сузыла торган булып китү

**Сузылмалана бару** Торган саен тагын да сузылмалану

**Сузылмалана башлау** Сузылмалык барлыкка килү

**Сузылмалана төшү** Бераз сузылмалану; тагын да сузылмалану

**Сузылмаланып бетү** Тәмам, бик нык сузылмалану

**СУЗЫЛМАЛЫ** *с. к.* **сузылма**. *Ул – җәелмәле караватта, хатыны – диванда, Светка, ягъни яңа кызы, үз буеннан күпкә кайтыш сузылмалы балалар караватында йоклады.* Ә.Мушинский

**СУЗЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сузу**

2) Буй юнәлештә урнашкан булу; озын булып күренеп тору. *Киң басулар сузыла еракларга, Як-ягына җитми карашың.* С.Урайский. *Басулар кардан арчылган, тик урманнан авылга таба сузылган тирән елга кары гына кояшка каршы күзне камаштырып ялтырап ята.* Г.Бәширов. *Алар заводка таба сузылган такыр юлдан берничә секунд сүзсез бардылар.* Г.Минский

3) Билгеле вакыт аралыгында дәвам итү. *Бер сәгатькә сузылган докладны бик зур дикъкать белән тыңладылар.* М.Гали. *Яңгыр озакка сузылмады.* Э.Касыймов

4) Гәүдәне сузып яту. *Ялчылар арганнар иде. Аш өенең сәндерәсенә сузылу белән үк үлек кебек йоклап киттеләр.* Г.Ибраһимов. *Тынып торганнан соң, башын селкеп куйды [кәҗә]. Ләкин ул бик хәлсез иде, шунда ук авыраеп тагы идәнгә сузылды.* А.Расих

5) Гәүдәне яки кул-аякны сузып үрелү; тотарга, алырга омтылу. *Фәлсәфәдән арган минутларында Муса мандолинага сузыла иде.* М.Максуд. *Айгыр, хуҗа кергәнне сизгәч, әкрен генә кешнәп җибәреп, Маликның кулына сузылды.* И.Гази

6) Гәүдәне киереп турайту. *– Атлар солыларын бетергәч, мине уятырсың... – ди [Фәйзулла] вә озын гына киерелеп сузыла да тиз хырылдап йокыга китә.* Ш.Камал. *– Болай итеп бер генә кеше дә киерелә, сузыла алмый! – ди ул миңа, бу юлы да салпы якка салам кыстырып.* Р.Батулла

**Сузыла башлау** Сузылырга тотыну; сузылуның башлангыч ноктасында булу. *Секциядәге көндәлек күнегүләр икешәр-өчәр сәгатькә сузыла башлагач, егетләргә өйләрендә кыздырган бәрәңге-чөгендер егәре генә җитмәс булды.* В.Имамов

**Сузыла бирү** Бернигә карамастан сузылу

**Сузыла төшү** Тагын да сузылу; берникадәр сузылу. *Урман һавасын сулыйсулый, печән әзерләргә китеп барган яшь ирнең ымсынуы озакка сузыла төште.* Д.Булгакова. *Яшь пәһлеваннарны бүләкләү бераз сузыла төште.* Безнең гәҗит

**Сузылып алу** Кыска вакытка гына сузылу

**Сузылып бару** Нindидер бер чиккә кадәр сузылу. *Ул Яңилгә таба сузылып бара да, аннан Мишә буена төшеп, тагын барып-барып, Идел ярларындагы урманнарга ук тоташа.* Г.Бәширов

**Сузылып бетү** Тәмам, бик нык, ахыр чигенә җитеп сузылу

**Сузылып калу** Берәр тәэсирдән соң сузылган рәвешен саклау. *Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга, һәм эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала.* Ә.Еники

**Сузылып китү** Кинәт сузылу; сузылган булу. *Зифа тәтәй әллә кайларга кадәр сузылып киткән биек юлга исе китеп карап барды.* Г.Бәширов. *Ул тагын да төкселәнеп, гәүдәгә сузылып китте кебек, аңа олылар төсе иңде...* Р.Батулла

**Сузылып тору** Гел сузылу; сузылган хәлдә булу. *Ямгырчы би кулындагы агач табакны шапылдатып бүкән*

*өстенә куйды, югарыдан сузылып торган җиз көпшәнең бөкесенә тотынды.* Н.Фәттах

**СУЗЫНКЫ** *с.* 1) Чагыштырмача озак дәвам итә, озаккарак сузыла торган (тавыш, аваз тур.). *Хәлсез иреннәрдән саркылып чыккан йомшак, сузынкырак тавышны һич онытмады.* Ф.Сафин. *Бүлмәне сузынкы моңсулык биләп алды.* А.Хәлим

2) Гадәттәгедән сузыбрак, озынрак итеп башкарыла торган. *[Әсәрнең] ялыктыргыч озын, сузынкы булуын да әйтергә кирәк.* М.Җәлил. *Элекке татар халык көйләре моңлы, сузынкы, төшенке, аһ-зар белән сугарылган булганнар.* Ватаным Татарстан

**СУЙДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сую**. *Кая ул атын суйдыру, кышын кар да сорап ала алмыйсың син Мөхәммәдәмин ханнан.* М.Әмирханов. *«Сугыштан кайтканнан бирле чебен дә үтергәнем юк, тамчы кан күрсәм дә, йөрәгем бозыла», – дип, тавыкны да күршеләреннән суйдыруы әнә шул хакта сөйли.* Г.Галиева

2) Кан күренер дәрәҗәдә ышкытып кырдыру, җәрәхәтләү, чиләндерү (тәнне). *Алдагы привалга кадәр бара мескен аксап-туксап. Бу инде ЧП! Бу инде аягыңны суйдыру, чиләтү, кабарту дигән сүз.* М.Ибраһимов

**Суйдырып алу** Тиз арада суйдыру

**Суйдырып бетерү** Барысын да суйдыру

**Суйдырып кую** Алдан суйдыру

**СУЙЛАК** I *с. диал.* Ялкау, иренчәк. *Нишләп ятасың монда, суйлак?* А.Гыйләҗев

**СУЙЛАК** II *с. иск.* Суелып, ашалып, кыршылып беткән. *Туң усакны кимрәкимрә, Алла, Тешем суйлак булды инде, Алла, туң кар өстендә йөгрә-йөгрә, Алла, Аягым туңгак булды, Алла.* Бәет

**СУЙЛАКЛАНУ** *ф. диал.* 1) Суйлак, иренчәк кешегә әйләнү

2) Ялкаулану; иренү. *Кече якта чаж да чож нидер пешерәләр, исе борынны кытыклый... Торырга бик вакыт! Тик кузгала алмый Гәрәй, суйлакланып ята.* А.Гыйләҗев

**СУКА** *и. а.х.* 1) Җир сөрү өчен, башлыча агачтан эшләнгән, сабаннан аермалы буларак җир катламын әйләндереп капламый торган авыл хуҗалыгы коралы. *Элек кенә безнең якларда авыл җирендә сөрү коралы сабан, сука булган.* Р.Әхмәтҗанов. *Сука белән җир сукалау калган Чабаталы мәэюс морзаларга.* Ж.Дәрзаман. *Кояш торган саен ныграк чыбыркылый, бүген-иртәгә язгы чәчүгә төшәсе, хуҗалыкта булган бөтен сука-тырмаларны, чәчүлек орлыкны барлап куясы бар.* В.Имамов

2) Җир сукалау эше. --- *талаша торгач, болар бервакыт җәй көне эшләрен алышканнар: хатыны басуга сукага киткән...* Әкият. *Кызу эш өсте, атлар буш түгел: кайсы урманда, кайсы сукада.* Т.Гыйззәт

◊ **Сука сукалау** 1) Җирне сука белән сөрү. *Үгез сука сукалый, Бозау тырма тырмалый.* Әйтем. *«Халык дошманы» гаиләсе булганлыктан, әни бар авыр эшләргә кушылды. Окоп казу, урман кисү, таш чыгару, сука сукалау.* Безнең гәҗит; 2) Иген игеп, крестьян булып гомер итү; гади игенче булу. *Феодализм начар булган, диләр, Сука сукалаган асыл ирләр, Эшләгән дә оброк түләгән, Яңа тормыш төзи белмәгән.* Г.Афзал. **Сука тоту** Сука белән җир сөрү; сукачы булып гомер итү, иген игеп яшәү. *Аның җәй буе урак урып, сука тотып биле авыртмаган.* А.Шамов

**СУКАЛА́У** *ф.* 1) Сука яки сабан белән сөрү, эшкәртү. *Җир сукалап интеккәнче, сатасың да аласың ризыкны Америкадан.* Т.Миңнуллин

2) *күч.* Берәр телдә азмы-күпме канәгатьләнерлек сөйләшә белү, яхшы ук сөйләшү. *Байтирәк халкының күбесе русча һәм чувашча шактый кыю сукалый.* Г.Бәширов. *Инглиз телендә фигыль заманына карап үзгәрә. Шуны аңлагач кына, әзме-күпме сукалау мөмкинлеге туды.* М.Юныс. *Татарчасын белә, урысчаны ипилек-тозлык сукалый, башкасы ни пычагыма.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Азмы-күпме канәгатьләнерлек укый-яза белү; хәреф тану. – *Грамотаң бармы? – Гарәпчә, латинча бераз сукалыйм. Теге узган ел керткән хәрефләре белән булып ук бетми әле.* М.Мәһдиев. *Өйрәнеп булмады укырга. Бераз сукалыйм – хәзер соң инде, җитмешнең теге ягына чыгып барам.* Н.Фәттах

4) *күч.* Сөйләү, фикер белдерү, әйтү. – *Дөрес сукалыйсың, акыллы хатын икәнсең, – диде бераз сүрелә төшкән әти.* Ф.Яруллин. *Үзең телдә дөрес сукалыйсың син, ләкин нигә шуны чынлыкта да саклый алмыйсың? Нигә?* М.Вәли-Барҗылы

5) Уен коралында берникадәр канәгатьләнерлек уйный белү, ярыйсы гына башкару

**Сукалап бетерү** Бар җирне дә сукалау; сукалауны тәмамлау. *Туктагыз әле, көн кич булып бара, ничек итеп ул биш гектар җирне бүген сукалап бетерергә соң?* Т.Гыйззәт. *Кишәрлекләрен сукалап бетергәч, малайлар үлән җыйдылар.* М.Хуҗин

**Сукалап йөрү** Сукалау белән мәшгуль булу. *Төштән соң куянга утырып чаба, көн тиз авыша, ди торган идек без җир сукалап йөргән үсмер чакта.* Ш.Галиев

**Сукалап китү** Сукалый башлау. *Туктар --- тракторын танк кебек бер урында зырлатып-биетеп алды да, тимер төрәнен тагы да катырак батырып, икенче якка сукалап китте.* Х.Ибраһим

**Сукалап ташлау** Тиз-тиз сукалау; аннан-моннан сукалау. *Алсудан да изгерәк кебек күренгән егет үзгәрә: болынны сукалап ташлый.* Р.Рахман

**Сукалап тору** Даими яки әледәнәле сукалау; хәзерге вакытта сукалау

**Сукалап чыгу** Башыннан ахырына кадәр сукалау. *«Әлифба»ны сукалап чыктык.* М.Вафин. *Хәлим колхоз сукасына ялынып тормады, суканы үзе ясады да кеше чиратында сукалап та чыкты.* Н.Кәримова

**Сукалап яту** *сөйл. к.* **сукалап тору**. *Әйбәт кенә сукалап ятканда, моның аты хәлсезләнеп буразнага егылган.* Р.Вәлиев

**Сукалый башлау** Сукаларга керешү. *Кайбер газетларның хәрефләре бер дә ачык төшми. Безнең кебек яңа сукалый башлаган кешеләргә бик кыен.* М.Гафури. *Жак хәзер немецча азрак сукалый башлаган иде.* Г.Әпсәләмов

**Сукалый тору** Нәрсәдер башланганчы сукалау

**СУКАЧЫ** *и.* 1) Сукада, җир сөрүдә эшләүче. *Әй сайрашып очкан кыр кош-*

*лары! Кыр-җирләргә төшми калмагыз, Кыр-җирләргә төшеп, гөлгә кунып, Сукачыга сәлам сайрагыз!* С.Рәмиев. *Милли бәйрәмебез Сабан туе, сукачылар ярышы флагларын күтәрү хокукы бирелде остазга.* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Гади крестьян, игенче. *Бел, мирза, мин – туганнан бирле сахра куенында тирбәлгән бер сукачы.* М.Фәйзи

**СУКБАЙ** *и.* **1.** 1) Билгеле бер эше, кәсебе булмыйча, урыннан урынга күчеп йөрүче ярымхәерче кеше. *Сукбай кебек япа-ялгызың читтә йөрмәссең инде.* А.Гыйләҗев. *Чыкты да подъезд янындагы эскәмиядә уйланып утыручы сукбай янына килеп басты.* А.Фәләхов

2) Йорты булмаган, теләсә кайда йөри торган кеше. *Кеше дәрәҗәсе кыл өстендә, кыл өзелсә – чүп өстендә, дигән әйтемне чүплектә актарынучы сукбайлар яныннан узганда искә төшерәм.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Эш, хуҗалык, тормыш алып бару һ.б.ш. мәсьәләләрдә җавапсыз, мәнсез, җиңел карашлы кеше. *Дөя бәһасе байлыкны кулдан ычкындырды, кадалгыры сукбай!* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Сукбайга (*1 мәгъ.*) әйләнгән, сукбайлык тормышына күчкән. *Исәнмесез, җилләр, туган җирләр! Кайтып килә сукбай улыгыз. Һәммәгез дә, шөкер, исән икән, Моннан соң да исән булыгыз!* Р.Миңнуллин

2) Йорттан бизү яки хуҗасыз булу сәбәпле урам тормышына күчкән (эт тур.). *Әй, Җамай, күр әле: бер сукбай эт сине күзәтә.* Р.Батулла. *Мине юлдаш санап ике квартал янәшәмнән теркелдәгән сукбай эт арыды бугай, бер ачык подъездга шылды.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Тәрбиячесе, караучысы булмаган, теләсә кайда йөри торган. *Гражданнар сугышы елларындагы сукбай малайлар*

**СУКБАЙЛАНУ** *ф.* 1) Сукбайга әйләнү

2) Сукбай кебек кылану

3) Берәр сәбәп (вахталы эш, командировкалар һ.б.ш.) аркасында юлда еш йөрү, озаклап гаиләдән аерым яшәү. *Аның ире [нефть разведкасында эшләүче] җитәрлек сукбайланган иде, аны семья белән яшәргә өйрәтәсе бар иде.* Ш.Бикчурин

**Сукбайлана башлау** Сукбайлануга табан бару

**Субайланып бетү** Тәмам сукбайлану

**Сукбайланып йөрү** Шактый вакыт сукбай булу. *Бервакыт, олы юлда озак сукбайланып йөргәннән соң, эзәрлекләүдән качып, караңгы төндә әнисе ишеген шакыган.* Риваять

**СУКБАЙЛЫК** *и.* Сукбай булу; сукбай тормышы; сукбай хәле. *Сукбайлыкта йөргән чагында, ул аз-маз язгалый иде.* Р.Батулла. *Сукбайлыкта өйрәнелгән начар гадәт онытылып бетмәгән, күрәсең.* С.Сабиров

**СУККАЛАНУ** *ф.* Тынгысызлану; ыгы-зыгы килү; бәргәләнү. *Күңелләр урыныннан купты, аерылу борчуы белән бәргәләнде, суккаланды.* Х.Камалов. *Ул соңгы көннәрдә җанын кая куярга белмичә бәргәләнеп, суккаланып йөрде.* А.Вергазов

**Суккалана башлау** Суккаланырга тотыну. *Габдулла, авыртуга түзә алмыйча, бәргәләнә, суккалана башлады һәм... уянып китте.* И.Нуруллин

**Суккаланып бетү** Тәмам, бик нык суккалану

**Суккаланып тору** Даими яки әледән-әле суккалану; суккалану хәлендә булу

**СУККЫЧ** *и.* Ашлык сугу машинасы. *Күчәрбай, чынлап та, үзе укыйяза белмәсә дә, ургыч, суккыч шикелле төрле авыл хуҗалыгы машиналарында эшли белә торган алтын куллы егет иде.* М.Әмир. *Шулчак Ярмөхәммәт суккычка яңа көлтә каптыра.* Р.Батулла

**СУКМА** *и. к.* **сукно**

**СУКМАК** *и.* Кешеләр, хайваннар йөрүдән тапталып ясалган тар гына юл. *Туры сукмак бар, ә син, үләннәрне таптый-таптый, нигәдер кырыйдан үрмәлисең, апа.* Н.Гыйматдинова

**СУКНО** *и. рус* **1.** Йоннан яки йон кушып тукыла торган йомшак тыгыз тукыма. *Чем-кара күзле, өстендә солдат сукносыннан тегелгән пальто, аягында --- калын табанлы ботинкалар...* З.Зәйнуллин. *Акчуриннарның Гурьевкадагы сукно фабрикаларын карап кайтты.* Р.Нуруллина

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Кодагый әби, калын сукно шәлен бөркәнеп, фонарь кабызды.* М.Мәһдиев

**СУКРАНУ** I *ф.* Кемне дә булса тиргәп яки зарланып үзалдына сөйләнү. *Бикташев сукранырга кереште: – Кая гына китеп бетәдер бу өйдә әйберләр, һич эзләп табарлык түгел!..* Н.Акмал

**Сукрана башлау** Сукранырга тотыну. *Сәлимә җиңги, алъяпкычы белән йөзендәге тирен сөртә-сөртә: – Хур булдык, оятлы булдык, бернәрсәм дә калмады. Нишлим инде? Нәрсә белән туйдырыйм инде боларны?.. – дип сукрана башлады.* К.Тинчурин. *Бәдри абзыйның Казаннан озак кайтмый йөрүе белән борчылып, Гайшә апа кайчагында сукрана башлый, ирләрне битәрләргә тотына иде.* Ә.Фәйзи

**Сукрана бирү** Бернигә карамастан сукрану; һаман сукрану

**Сукрана төшү** Бераз сукрану; тагын да сукрану

**Сукранып алу** Бер ара, аз гына сукрану. *[Зарифатти] Атларга ирек бирмичә, аяк астында өелеп яткан кар өемнәренә, урам җыештыручыларга сукранып алды.* Н.Акмал

**Сукранып кую** *к.* **сукранып алу**. *--- Намаҗан карт, бишбилле кара тун, камалы бүрек, кыска кунычлы киез ката киеп, күршесендәге мәчеттән кайтып килә иде. Килеп җитәрҗитмәс, гүя үзалдына сөйләнепсукранып куйды ---.* Г.Ибраһимов

**Сукранып тору** Даими яки әледәнәле сукрану; сукрану хәлендә булу

**СУКРАНУ** II *и.* Шундый кыланыш; шундый сүзләр. *Мәхлук җаннарның сукрануы – йогышлы чир.* Т.Миңнуллин. *«Нишләп йөрисез, эшкә соңга каласыз!» – дип сукрану ише сәерлекләре еш кабатлана башлады.* М.Маликова. *Элек күбрәк зарлану, сукрану белән алдыра торган булса, хәзер кешеләрне мактап, дәртләндереп эшләтә.* Р.Вәлиев

**СУКТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сугу**

2) Машина яки ат белән ашлык сугу. *Чиста, чүпсез арышны тиземгә салмый, турыдан урып суктыру ягын карарга кирәк.* Х.Камалов. *Башта чәчү, печән әзерләү, чак кына хәл алырга да өлгермисең – урак өсте, көлтә кертү,*

*ындыр суктыру.* М.Хәсәнов. *Ындырдагы бар кешене биетеп, ашлык суктыру машинасында эшләгән кырыс агай искә төшә.* Ш.Галиев

3) Кыйнатып, җәза бирү. *Төтенле базга ябу, чыбык белән суктыру дисеңме – берсе дә калмады.* Г.Бәширов. *Таяк белән суктыру гадәте шулай ук күчмәләр иҗаты була алмый.* Н.Фәттах

4) *күч.* Читләтеп сөйләү, кинаяләү. *Син нәрсә, һаман миңа шул турыда суктырып сөйлисең.* Т.Гыйззәт

5) *күч.* Талымсызланып, бик күп ашау. *Ипине дә матур гына суктыра ул!* З.Мансур

**Суктыра башлау** Суктырырга тотыну. *Бөтенесе дәррәү теземнәрне суктыра башладылар, Илһам гына комбайнын кабызмады.* Ф.Садриев

**Суктыра бирү** Бернигә игътибар итми суктыру

**Суктырып бетерү** Барысын да суктыру. *Бөтен авылның йорт тәрәзәләренә такта суктырып бетерә бит инде ул.* М.Мәһдиев

**Суктырып кую** Алдан яки тиз генә суктыру. --- *ни эшләтсәләр дә эшләтерләр дип, тагын шактый солы суктырып куйдым, һәм атларга көн саен дүртәр кило солы ашата башладык...* В.Нуруллин

**Суктырып тору** Гел, даими, әледәнәле яки хәзерге моментта суктыру. *Аннары ул да хәзер, сугыш елы законнары буенча, Сафьянның әүвәлге тимерчелек мастерскоенда эшли башлаган, кадими заманнардан калган борынгы станокта калайдан солдат төймәләре суктырып тора иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**Суктырып утыру** Хәзерге моментта суктыру белән мәшгуль булу

**СУ́КУЫШ** *и. махс.* Судноның сыйдырышлыгын чагылдырган күрсәткеч: судноның суга батып торган өлеше этеп чыгарган су күләме

**СУ́ КЫЗЫ** *и. миф.* Рус һәм Көнбатыш мифологиясендә: таралып торган озын чәчле, балыкныкы шикелле койрыклы, төрле халыкларда чибәр яки ямьсез хатын-кыз кыяфәтле суда яши торган зат. *Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне! Алар тузылып төшсен алдыңа. Шулай килешә сиңа. Су кызыдай Кил дә хәзер минем алдыма, Утыр, күлдә шәүләң уйнасын; Узган-барган кешеләр туктап карап, Су кызы дип сине уйласын!* Һ.Такташ. *Борынгы Грециядә безнең су аналары шикелле чибәр су кызлары турында легендалар булган, бу су кызларын нимфалар дип йөрткәннәр.* Робинзон эзләреннән

**СУКЫР** *с.* **1.** 1) Күрү сәләтеннән мәхрүм, күзе күрми торган. *Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде.* Ә.Еники. *Карт елмайды, аның ике сукыр күзенә дә мөлдерәмә яшь тамчылары тулды.* Р.Батулла

2) *хурл.* Начар күрүче яки кылый күзле. *Аңа каршы берничә кеше көлешеп: – Әнә Наратлык аермасына җитеп киләләр ич! Сукыр, кая карыйсың соң син! – диештеләр.* М.Гали

3) *күч.* Әйләнә-тирәдәге эшләрне аңламый, хәлне белми торган, бик игътибарсыз. *Сукыр син, Касыйм! Әллә каян килеп чыккан бер башкорт кызына капланып төштең.* Х.Сарьян. *Йөрәк әллә нишләп китте. Сукыр икән бу, кеше белән кешене аера белми.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Ахмак, надан, томана. – *Син аның кем икәнен беләсеңме? Юк, белмисең, сукыр син, надан, йөрәксез! – дип тузынган Сәрби апа.* Г.Гомәров. *Без сөюдә сукыр, чукрак, надан, Без бит гомер буе көтүдә.* Л.Кәшфи

5) *күч.* Яктылыгы булмаган, утлары күренмәгән; каплап, томалап, кадаклап куелган (тәрәзә һ.б.ш. тур.). *Сукыр тәрәзәләр белән бергә йортлар үзләре дә, урамнар да берәм-берәм күздән югалганнар.* М.Кәбиров. *Тактадан корыштырган нәни куыш. Бер тәрәзә, ул да булса ярым сукыр.* И.Рәмиев. *[Авылның] башта мәчет манаралары, анналары ике катлы берничә йорты, иң ахырда сукыр тәрәзәле, «сәҗдәгә киткән» тәбәнәк өйләре күренде.* И.Туктар

6) *күч.* Чыгу юлы булмаган. *Сукыр тыкрык* // Ике терәк арасындагы уемы үтәли булмаган. *Сукыр а́ркалар теземе*

7) *күч.* Бозык, кортлы, төшсез (чикләвек, җимеш һ.б.ш. тур.). *Сукыр чикләвек*

8) *күч.* Күзсез, ватык (энә һ.б.ш. тур.). *Колхозның сукыр инәсенә кадәр кай җирдә ятканын күңелдән белә торган кешебез – завхозыбыз.* Т.Гыйззәт. *Мөхәммәтҗан солдат аңа ачуланып кычкырды: – Малдамыни хәзер эш? Менә миңа кешенең, можыт, сукыр инәсе дә кирәкмидер.* Г.Бәширов

9) *күч.* Тишелгән, бозылган, гомумән, кулланыштан төшкән (металл акча һ.б.ш. тур.). *Сукыр акча. Сукыр тәңкә*

10) *күч.* Кеше ихтыярында булмаган, очраклылыкка нигезләнгән, стихияле (табигать көчләре һ.б.ш.). *Фән белән яктыртылмаган практика – сукыр практика ул.* Р.Ишморат

11) *күч.* Анык нигезе, әһәмиятле сәбәбе булмаган, акылга нигезләнмәгән. *Андый сукыр дисциплина буламы?* Г.Ибраһимов. *Капма-каршы хисләр утында яна ул: тирән шомлану йөрәген биләп ала, сукыр көнчелек акылын томалый.* Ә.Еники. *Аның күңелендә ниндидер сукыр ачу, ярсу кабара башлады.* Н.Фәттах

12) *күч.* Яктыны бик аз бирә торган. *Бер почмакта сукыр ут яна, идәнгә салам түшәлгән.* Х.Камалов. *Сукыр лампага ашыгып ут элделәр, янып-пешеп эшкә тотындылар.* В.Имамов

**2.** *и. мәгъ.* Күзе күрмәгән яки начар күргән кеше. *Татарда, аяксыз күп йөрер, сукыр күп күрер, дигән мәкаль бар.* Ф.Яруллин. *Тиле, әллә шул сукырның сүзенә карап өйләнер идеңме?* Н.Кәримова

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Күрмичә, күрү сәләтен югалткан көе; сукырларча. *Боларны искә төшерүем минем шуның өчен: без үзебезнең ферма малларын карауда борынгыча сукыр булмыйк, дим.* Ә.Еники. *«Мин сукыр көе күзлеләрдән күбрәк күрдем, дөньяның ямен күбрәк тойдым», – дигән гомере сукырлыкта үткән гарәп шагыйре Мәгари.* Г.Хөсәенов

2) *күч.* Берсүзсез, тулысынча ышанып, буйсынып, ихтыярсыз. *Адәм, син берәүгә дә сукыр килеш ышанма!* Г.Коләхмәтов

◊ **Сукыр бәхет** Очраклы рәвештә генә ирешелгән уңыш; бәхетле очрак. *Билгеле, үзеннән-үзе генә, көтмәгәндә генә килеп чыккан сукыр бәхет түгел инде бу.* Л.Шагыйрьҗан. **Сукыр да күрерлек** Теләсә кем күрерлек, ачык, күренеп-беленеп тора торган; һәркем аңларлык. *Байлык-җитешлекнең ни*

*икәнен сукыр да күрерлек, саңгырау да ишетерлек итеп тырыштылар.* Р.Мулланурова. **Сукыр күзгә дә күренә** *к.* **сукыр да күрерлек**. *Имза куелуын куелган, тик сукыр күзгә дә күренә: Фәрит Идиятуллинның имзасын башка берәү сырлаган...* Э.Фатыйхова. **Сукыр тавык** *хурл.* 1) Бик начар күрүче яки бик игътибарсыз кешегә карата. *Сез, сукыр тавыклар, аның өненә барып менгәнсез.* А.Гыйләҗев. *Әнә теге велосипедлы аңгыра, кинәт борылыштан чыгып, машина астына керә язды. Сукыр тавык!* Ф.Яруллин; 2) Надан, аңгыра кеше турында. *Надан кеше – сукыр тавык.* Мәкаль. **Сукыр тиен дә** Аз гына булса да; бөтенләй. *– Синдә берәр тәңкә генә калмадымы соң? – дип сорап куя миннән юлдашым. – Тәңкә түгел, Сәлихҗан, сукыр бер тиене дә калмады, – дим.* К.Миңлебаев. *Җыештыручының хезмәт хакы күпме генә инде, миннән дә сукыр тиен дә ярдәм юк, җиңел түгелдер Вәсиләгә.* Г.Галиев

**СУКЫРАЮ** *ф.* 1) Күрү сәләтен югалту, сукырга әйләнү, күрми башлау. *Минем атам Мөхлисулланың әтисе, ягъни минем бабам Кәлимулла, тома сукыр иде: аның бер күзе Ярман сугышында кыйпылчык кереп сукырайган...* Р.Батулла. *Үзенең егерме яшеннән шушындый хәлдә булуыннан да, Фәргатьнең сукыраю хәбәреннән дә --- үзәге өзелеп, ул чарасыздан елый башлады.* Ф.Бәйрәмова

2) *күч.* Бик игътибарсызга әйләнү, тормышны, хәлләрне аңламас хәлгә килү. *Гашыйк кеше ул тәмам сукырая.* М.Максуд

3) *күч.* Күңел сизгерлеген жую, катыру, каты бәгырьлегә әйләнү. *Район оешмаларының кулы җитми. Үз мәнфәгатьләре белән сукырайган бер төркем кешеләр табигатьне талауларын сизми калалар.* А.Гыйләҗев. *Тәкәбберлек агуыннан сукырайган күңелләре Аллаһының барысыннан да көчлерәк булуын онытып җибәрде.* Туган як

**Сукыраеп бару** Акрынлап сукыраю. *Бераз соңрак чын мәгънәсендә могҗиза барлыкка килде: сукыраеп барган теге күз тәмам ачылды ---.* Х.Гәрәй. *--- инде татарны агартыйм дип, үзем каралып киләм, күзләрен ачыйм дип, үзем сукырая барам...* Ә.Фәйзи

**Сукыраеп бетү** Тәмам сукыраю. *Җитәкчеләр идея белән сукыраеп беткәннәр, шуннан башка нәрсәне күрмиләр.* Х.Камалов

**Сукыраеп калу** Берәр вакыйгадан соң, тәэсирдән соң сукыраю. *Аннары урам чатларына автомобильләр килеп тыгылды, чөнки яшелле-кызыллы светофорлар сүнеп, сукыраеп калганнар иде.* А.Тимергалин

**Сукыраеп китү** Әкренләп сукыраю. *Борын-борын заманда, ди, чал чәчле бер әби сукыраеп киткән.* Н.Каштанов

**Сукырая бару** Торган саен тагын да ныграк сукыраю

**Сукырая башлау** Сукыраюга табан бару. *Ул үзенең сукырая башлавын тойды.* Г.Гыйльманов

**Сукырая төшү** Тагын да сукыраю

**Сукырая язу** Чак кына сукыраймый калу. *Бер туганыбыз грипптан сукырая язды, икенче туганыбызның борынында тыңкышлык әле дә бетми.* Ф.Яруллин

**СУКЫР КЫЧЫТКАН** *и. бот.* 1) Иренчәчәклеләр семьялыгыннан вак кына ак чәчәкле, каралты-кура коймасы, ерымнар буйларында куе булып үсә торган кычытканга бик охшаш, ләкин чакмый торган яфраклы үлән үсемлек; ак баллут, баллы баба, балдыган; *русчасы*: **яснотка белая**. *Яшел таплы җир өстендә күгәргән, мүкләнгән нигез ташлары арасыннан юан сабаклы алабуталар, карга борыннары, сукыр кычытканнар үсеп чыккан.* А.Гыйләҗев. *...Алдымда зур итеп «Өшәр» дип язылган тимер. Аның артында сукыр кычыткан, тигәнәк, җитен, әрем басуы шаулый.* Л.Шәех

2) *диал.* Арыслан койрыгы, йөрәк уты; *русчасы:* **пустырник**. *Янына чыгып, валидол я булмаса сукыр кычыткан төнәтмәсе эчертәсеме соң, дигән уй чагылып үтте.* Ф.Җамалетдинова

**СУКЫРЛАНУ** *ф. к.* **сукыраю**. *Вә ләкин ул күңелнең сахибы күрми сукырланса, Күңелдән тар бер әйберне табып булмыйдыр ул чакта.* М.Гафури. *Яхшы-яман якны аерырга Сукырланса күңел күзлегем, Адаштырмас тормыш чатларында Әнкәй сөте биргән үзлегем...* Ф.Дәүләтгәрәева

**Сукырлана бару** Акрынлап сукырлану

**Сукырлана башлау** Сукырлануга табан бару

**Сукырлана төшү** Бераз сукырлану; тагын да сукырлану

**Сукырланып бетү** Тәмам сукырлану

**СУКЫРЛЫК** *и.* 1) Сукыр булу хәле, күрү сәләте булмау. *Сукырлыкны язмыштан тыш юллап, Мич башында көтеп алмадым.* Ф.Шәехов. *Анай мәрхүмәнең, урыны җәннәттә булсын, йөккә узгач, лимон кабасы, шуның белән чәй эчәсе килгән. Ә лимон юк. Табиблар да сукырлыгымны шуннан күрә.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Томаналык, наданлык; рухи чикләнгәнлек. *Мин боларның тупаслыгына, аяз көндә кояшны күрә алмауга охшашлы сукырлыкларына хәйран калам.* Г.Ибраһимов. *Безнең аң сукырлыгы, шаблонга күнегү яралыларның үлеменә китерә...* Х.Камалов

**СУКЫР ТӘКӘ** *и. сөйл.* Күз бәйләш уены. *– Тукта әле, Әпипә, – диде [Айсылу]. – Без синең белән сукыр тәкә уйнамыйк әле, яме?!* Г.Бәширов

**СУКЫР ТӘКӘЛЕ** *и. сөйл. к.* **сукыр тәкә**. *Матур сүзләр белән минем күзләремне томалап, Зиннур малай белән сукыр тәкәле уйнарга телисең!* Т.Гыйззәт. *Сукыр тәкәле уйныйбыз, сукыр тәкәле!* Н.Кәримова

**СУКЫР ТЫЧКАН** *и. зоол.* Сукыр тычканчалар семьялыгыннан алгы аяклары җир казу өчен җайлашкан, башлыча бөҗәкләр белән туклана торган җир асты җәнлеге, имезүче хайван; *русчасы*: **крот**. *Әнә шулай итеп сукыр тычкан – җилне, җил – камышларны, камышлар су өстендәге дулкыннарны уяткан.* Ф.Яруллин. *Утыра-утыра, без сукыр тычканнар турында да, күзле тычканнар турында да фәлсәфә саттык.* Ф.Абдуллин

**СУКЫР ТЫЧКА́НЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Имезүчеләрнең бөҗәк ашаучылар отрядыннан су шолганы, сукыр тычкан, көрәнтеш кебек җәнлек төрләрен берләштерә торган семьялык

**СУКЫР ЧЕБЕН** *и. зоол.* 1) Парканатлылар семьялыгына караган, күкәй, личинка, курчак, имаго юлы белән үсә торган вак бөҗәк; күпләп, мыжгып оча торган өердәге черки; ләпәк. *Сукыр чебен күзгә кермәсә, аны сукыр да димәсләр иде.* Г.Әпсәләмов. *Биредә һичбер борчучы юк. Очмый хәтта сукыр чебен дә.* З.Мансур. *Урманда черки, сукыр чебен күренми.* И.Кашфразыев

2) *күч.* Әрсез, бәйләнчек, бертуктаусыз борчып торучы кеше. *Җибәрми нишләсеннәр, сукыр чебен шикелле эшкә билгели торган вакытка туры китереп йөргәч.* М.Юныс. *Шул көнне Вася-Василий, бер сукыр чебенгә юлыгып, каты гына яраланган, госпитальгә озатылган!* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Сукыр чебен тешләү** Нindидер сәбәпләр аркасында тынычсызлану, борчулы булу. *– Нинди сукыр чебен тешләде соң әле бу баланы? – дип, үзенчә фикер йөртте ул [Гөлбикә апа].* Ж.Дәрзаман

**СУКЫР ЧЕРКИ** *и. зоол. к.* **сукыр чебен**. *--- төне буе битем белән кулларымны озынборын белән сукыр черки талап чыкты.* Г.Бәширов. *Забой өстендә күгелҗем эңгер, көтү-көтү булып мыжылдап торган сукыр чебен. --- Биткүзне сукыр черки сырып алды.* И.Салахов. *Директорның каршына сукыр черки кебек килеп чыгарсың.* В.Нуриев

**СУКЫР ЭЧӘК** *и. анат.* Кешедә, кайбер имезүче хайваннарда, кошларда нәзек эчәкнең юан эчәккә тоташкан урынында кечерәк кенә капчык шикелле үсенте. *Йөрәкләрегезне – бавыр, бавырларыгызны сукыр эчәк урынына утыртып кую минем өчен берни тормый.* Ф.Яруллин

**СУЛ** *с.* 1) Гәүдәнең йөрәк урнашкан ягындагы; уңның каршы ягындагы. *Сул кулы белән Кави дүрт яшьлек энесе Рәшитне җитәкләгән.* З.Зәйнуллин

2) Шул яктагы, шул якта урнашкан. *Мөселман кануннары буенча бездән кырык йорт алда, кырык йорт артта, кырык йорт уңда, кырык йорт сулда яшәгән җан ияләре күршеләр дип атала.* А.Хәлим. *Ә чак кына сулдарак – бик күп риваятьләрдә телгә алына торган Кабан күле...* М.Хәсәнов

3) Сул (*1 мәгъ.*) кулныкы яки сул аякныкы (кул-аяк киеме тур.). *Сул бияләй озаккарак чыдый*

4) Йөз белән агым юнәлешенә, түбәнгә таба карап торганда сул (*1 мәгъ.*) якта булган (яр тур.). *Район үзәге Иртыш елгасының сул ярында урнашып сазлык белән әйләндереп алынган, ә каты япмалы федераль юл елганың уң ягы буйлап сузылган.* И.Кашфразыев

5) Аскы, эчке, тискәре; тыштан караганда күренми торган (кием, материал һ.б.ш.ның ягы тур.). *Койганда эретелгән металл тәңкәнең уң һәм сул ягы көзгедәгечә язылган йомшак таштан эшләнгән калыпка куелган.* А.Мөхәммәдиев

6) *кит.* Сәяси яктан кыюрак, кискенрәк һәм алдынгырак карашны яклаучы. *[Хөсәен:] Легаль, ләкин бик сул, дөресен генә әйткәндә, прогрессив идеяләрне пропагандаларга тиеш булган газета чыгарырга җыенабыз.* А.Расих

7) *күч.* Дәүләт яки җәмгать милкеннән, җиһазыннан-коралыннан, эш урыныннан файдаланып эшләнә, ләкин кереме, табышы-файдасы эшләүченең үзенә була торган һ.б.ш. (эш, кәсеп тур.)

◊ **Сул аягы ни кушса, шуны эшләү** Уйламыйча эшләү, мантыйкка нигезләнмичә эш итү; холыксызлану, дуамаллану. *--- Никита Сергеевич Хрущёвның соңга табан артык дуамалланып, сул аягы ни кушса, шуны эшли башлавы югары җитәкчелектә утыручыларның да күбесен бик туйдыргандыр, ахрысы…* Ә.Еники. **Сул ягы белән торган** Кәефсез, ачулы, үпкәле кеше турында. *Җаббар абзый, син бүген сул ягың белән торгансың ахры: һәрбер сүзгә тискәре барасың.* Г.Ибраһимов. **Сулга эшләү** Дәүләт яки җәмгать җиһазыннан-коралыннан, эш урыныннан файдаланып, эшләүченең мәнфәгатен күздә тоткан эшләр башкару. *Алар [кайбер шофёрлар] – юк-бар бер сум хакына сулга эшләргә омтылучы кешеләр, дигән фикер туган.* Ватаным Татарстан

**СУЛАГАЙ** *с.* **1.** 1) Сул (кул тур.). *«Булдыксыз» иренә сулагай кулын селтәгән җиңги бу юлы үзе алышырга исәп итте, күрәсең.* Ф.Абдуллин. *Фәкать язуның сулагай кулдан язылуы өчен, минем улыма сылтап, бернинди шаһитсыз суд ясап, улыма сигез ел бирәләр, һәм шуннан кайта алмады.* Д.Гатин

2) Һәрнәрсәне сул кулы белән эшләргә күнеккән яки гомумән сул кулы белән генә эшләгән (кеше тур.). *Уң кулы протезлы булганга, ул сулы белән яза иде. Аңа укучылар «сулагай абый» дип кушамат та кушып өлгергәннәр иде инде.* К.Латыйпов. *Шулчак Дамир авылда бер сулагай укытучының тактага акбур белән дә, кәгазьгә ручкакаләм белән дә сырлап, матурлап язуын хәтерләде ---.* С.Шарипов

3) *күч. ирон. к.* сул (*7 мәгъ.*). *Ул кайбер сулагай эшләрне киявеннән яшереп тә калдырды.* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* Һәрнәрсәне сул кулы белән эшләргә күнеккән яки гомумән сул кулы белән генә эшләгән кеше. *Сулагайның да уң кулы бар бит.* Э.Шәрифуллина. *--- 1992 елдан, Бөекбританиянең сулагайлар клубы башлангычы буенча, 13 август Бөтендөнья сулагайлар көне буларак билгеләп үтелә.* Ирек мәйданы

**3.** *рәв. мәгъ.* Сул кул белән, сул кул ярдәмендә. *Ник Фасил болай сулагай көрәшә?* Ә.Баян. *Сәлимә сулагай ура икән.* Г.Бәширов

**СУЛАГАЙЛАП** *рәв.* Сул кул ярдәмендә, сул кул белән. *[Нәҗибә:] Ошамаганны сөйләмәсәнә! Сулагайлап салып җибәрермен, җыбыткы.* А.Гыйләҗев. *Абзый кеше егеткә «әнкәсен» искә төшереп, сулагайлап, алагаем кулы белән берне селтәп җибәрде.* А.Хәмзин

**СУЛАГАЙЛЫК** *и.* Сулагай (*2 мәгъ.*) булу хәле. *Элек сулагайлык нормадан тайпылыш, җитешсезлек булып санала иде.* Гаилә һәм мәктәп. *Сулагайлык проблемалары буенча галимнәр һаман да бер фикергә килә алмый.* Кызыл таң

**СУЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сулау** I

2) Дымлану, юешләнү; чылану. *Кулында аның суланган мимоза букетлары.* М.Җәлил. *Суланып бүрткән рамнарны ике куллап этә торгач, тәрәзәне ачып җибәрдем.* А.Гыйләҗев

3) Тәндәге кабарган жир, җәрәхәт һ.б.ш.ларга сөл тулу, юешләнү, чиләнү

**Сулана бару** Һаман акрынлап сулану

**Сулана башлау** Суланырга тотыну. *Янгында кызарган тән, урыны-*

*урыны белән кабарып, сулана башлады.* Ә.Маликов

**Сулана төшү** Берникадәр сулану; тагын да ныграк сулану

**Суланып тору** Даими яки бертуктаусыз сулану; суланган хәлдә булу. *Баржа иске. Урынында торганда да трюмы суланып тора.* Ш.Усманов

**СУЛА́У** I *ф.* Сулы итү, су белән чылату, юешләү. *Ул кара такта янына килде, чүпрәген сулады да тактаны сөртә башлады.* Г.Гобәй. *Сохарилары күгәрә төшсә дә, суласаң шома үтә икән.* И.Туктар

**Сулап алу** Бераз сулау; тиз генә сулау

**Сулап кую** Суланган итү

**Сулап тору** Даими яки бертуктаусыз сулау

**Сулый төшү** Бераз сулау; тагын да ныграк сулау

**СУЛА́У** II *ф.* 1) Сулыш юллары аркылы үпкәгә һава алу һәм аны чыгару, тын алу һәм тын чыгару. *[Фатыйма] Яшьләренә буылды. Яшь арасында ешеш сулады.* А.Нәҗми

2) Организм эшчәнлеге өчен кирәк булган кислород алу. *Һава кешеләргә, хайваннарга һәм үсемлекләргә сулау өчен кирәк икәнен сез беләсез инде.* Материклар һәм океаннар географиясе

3) Кемгә, нәрсәгә дә булса сулышны юнәлтү; сулыш җибәрү

4) Һава агымы, сулыш белән эчкә алу, суыру. *Күкрәк тутырып баллы ипи, салат исен сулап барган уңайдан Асаф кинәт кенә әкият кызына әверелгән сихри бу гүзәлгә күз ташлады.* М.Мәһдиев. *Гомәр абыйга күрше булып яшәдем. Көн саен диярлек икәүләп һава сулап йөрүләр гадәткә әйләнде.* М.Әхмәтҗанов

5) *күч.* Һава үткәрү. *Бу резин итек суламый*

**Сулап алу** Бераз сулау. *Ул тагын бер мәртәбә авыр сулап алды да аһылдап җан тәслим кылды.* Г.Гыйльманов

**Сулап кую** Бер мәртәбә сулыш алу. *Гөлзәминә карчык, хатны онытына тоттыргач, күкрәгендә җиңеллек сизеп, иркен итеп сулап куйды.* Ф.Яруллин. *Газиз карт бу юлы җавап бирмәде, авыр сулап куйды да кайту ягына кузгалды.* Г.Гыйльманов

**Сулап тору** Даими яки әледән-әле сулау; хәзер сулау

**Сулый башлау** Суларга тотыну. *Үрләр менгәндә сиздерә, Авыр сулый башладым.* Р.Шәймәрданов

**СУЛКЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сулкылдау**. *Билгесезлек дип аталган тәшвишле уй-шөбһә җанын кыйный, ачык җәрәхәткә салынган тоз шикелле бәгырен телгәли, сулкылдата иде.* Ф.Латыйфи. *Чынлап та, әби-бабайларның беренче мәхәббәтнең, беренче хәләл җефетеңнең беркайчан да онытылмавы, йөрәккә кадалган шырпы кебек гел җанны сулкылдатып торуы хакындагы сүзләре дөрес, ахры.* Идел

**СУЛКЫЛДА́У** *ф.* 1) Авырлык килгән, җәрәхәтләнгән һ.б.ш. урын пульс тибеше кебек авыртып, өзек-өзек сызлап тору. --- *аның [Фәезнең] яңак сөякләре бик сызлый, аскы ирен бияләй булып асылынган, күз төбе шешеп килә, кыза, сулкылдый иде.* М.Мәһдиев. *Ящиклар күтәреп сулкылдаган беләкләр язылганчы, Ильяс сабыр гына көтеп утырды.* Р.Төхфәтуллин

2) Гадәттә елаган вакытта кискен һәм өзек-өзек сулыш алу; үксү. *Михаил мендәргә капланып сулкылдый иде.* М.Кәбиров. *Сулкылдый-сулкылдый, бәргәләнә-бәргәләнә, туйганчы елады [Галия].* Л.Ибраһим-Вәлиди

3) *күч.* Нindидер авыр, тискәре уй, хис һ.б.ш.лардан йөрәк авырту, күңел әрнү. *Бу коточкыч авазлардан колагым тона, йөрәгем сулкылдый.* И.Салахов

**Сулкылдап алу** Бер ара сулкылдау; аз гына сулкылдау. *Күптән булган бу кичләрне исенә төшереп, Рәйханның йөрәге бертөрле әрнү белән сулкылдап алды.* Д.Каюмова

**Сулкылдап кую** Бер мәртәбә сулкылдау. *Әйләнә-тирәдә салам кыштырдап ала, авыр сулаган, сулкылдап куйган тавышлар ишетелә.* Г.Бәширов. *– Юк! – диде Мөбарәк һәм җилкәсен калтыратып сулкылдап куйды.* М.Шаһимәрдәнов

**Сулкылдап тору** Сулкылдау хәлендә булу

**Сулкылдый башлау** Сулкылдарга тотыну. *Әйләнә-тирәсен онытып, ул [Газизә] үзенең йөрәк төбеннән кайнашып менгән ачы яшьләренә тулы ирек бирде һәм, иңбашларын бер күтәреп, бер төшереп, бик нык сулкылдый башлады.* Ә.Фәйзи. *Табиб кабинетында ук сулкылдый башлаган йөрәк әрнүе чигенә җитеп, Фирүзә кычкырып җибәрде.* Айзирәк

**СУЛЛАП** *рәв. сөйл.* Сул кул ярдәмендә яки сул кул, сул як белән. *Югыйсә без трибунага телевидение, радио башлыгын чыгарып бастырабыз да аны уңлап, суллап яңаклыйбыз.* Т.Миңнуллин. *Суллап эшләү*

**СУЛЛАШУ** *ф.* 1) Радикальләшү, кискенләшү, социалистлашу (караш, фикер һ.б.ш.лар тур.)

2) Социалист карашларга күчү, сулга (*6 мәгъ.*) әйләнү, сул булып китү. *Сәяси яктан ул хәзер шактый суллашты, кызылланды.* С.Җәлал. *«Әл-Ислах» комитеты торган саен суллаша, өлешчә эсерлар, башлыча социал-демократлар йогынтысына бирелә.* Р.Әмирхан

**Суллаша башлау** Суллашуга табан үзгәрү

**Суллашып бетү** Тәмам суллашу

**Суллашып китү** Билгеле моменттан башлап суллашу. *Мәгълүм ки, 1905 елның инкыйлаб җиле (җене дип тә әйтергә була) япь-яшь Тукайга да кагылмыйча калмый. Шуның аркасында ул берара шактый суллашып та китә.* З.Хөснияр

**СУЛЛЫК** *и.* Сул (*6 мәгъ.*) карашлар, суллар позициясе. *Сәяси суллык*

**СУЛУ** I *ф.* 1) Шиңү, пәжү (үсемлек тур.). *Бакчада сулды чәчәкләр, Төшкәч көзге кыраулар.* Ә.Исхак. *Сулды гөлләр йөзе, Өзгәләнгән чәчәкләрне Кулга алып иркәләдем, Назланып Хушланды гөлләр Җылы куллардан, Һәм дә балкып алды Соңгы тапкыр алар...* Ф.Яхин

2) Көю, кибү, төссезләнү, баштагы матурлыгын югалту (табигать тур.). *Яңгыр үткәч, тагын җанланалар Сулган гөлләр, сулган далалар.* Ә.Ерикәй

3) Ябыгу нәтиҗәсендә төссезләнеп, ямьсезләнеп калу (бит, йөз һ.б.ш. тур.). *Мае бетеп, пыскып утырган лампаның ялкын теле кинәт сикереп куйды, һәм шул ук минутта, ишек ачылып китеп, өйгә чандыр гәүдәле, сулган йөзле, озын саргылт мыеклы яшь кенә бер кеше*

*килеп керде.* М.Галәү. *Ул шушы берничә ай эчендә бик нык таушалган: күз төпләре капчыклана башлаган, битләре дә, иреннәре дә сулган.* Г.Бәширов

4) Бирешү, бетеренү, өшәнү. *Әйтсәгезче, якын дус итеп, Кайгы белән сулган анага...* М.Җәлил. *[Гөлҗиһан] кайчандыр таза һәм чибәр генә булып, хәзер инде сулган һәм күләгә генә булып калган.* И.Гази

5) *сөйл.* Берникадәр кимү яки бетү (чибәрлек һ.б.ш. тур.). *Ул ябыккан, агарган, әмма элекке матурлыгы сулмаган әле.* Казан утлары

6) *күч.* Нindидер хисләр сүрелү. *Бөредә сулды сөю, Ата алмады чәчәк.* Ф.Галиева

**Сула бару** Торган саен сулу. *Сөрмәя көннән-көнгә сула барып, кайбер вакытларда аяксыз да калгалап, урын өстенә егыла торган иде.* Ф.Яхин. *Хәмит көн дә эштән хәлсезләнеп кайтып егыла, күзгә күренеп сула барды.* Д.Каюмова

**Сула башлау** Сулуга таба бару; сулырга тотыну. *Мәхәббәт ул – гөлчәчәк, көн саен су сибеп тормасаң, сула башлый, аннан соң тәмам корый.* Р.Батулла

**Сулып бару** *к.* **сула башлау**. *Минем чәчәк инде сулып бара...* Ә.Хафизулла

**Сулып бетү** Тәмам сулу. *Мин сулып беткән булыр идем, фәкать ул җан бирә.* М.Гафури

**Сулып калу** Берәр тәэсирдән соң сулган хәлгә килү. *Аларның кайберләре инде бик иртә кырау суккан чәчәк төсле сулып калган.* М.Галәү

**Сулып китү** Кинәт сулу. *Нинди сөйкемле алсу йөзе дәррәү сулып китте Гөлсем апаның.* Г.Гобәй

**СУЛУ** II *и. к.* **сулыш**. *Заһит тиз генә сулуы белән аны җылытырга тотынды, кош та азрак селкенә башлады.* С.Жәлал. *Мин сулу саен сине көттем, килереңә ышандым.* Д.Аппакова

◊ **Сулу кабу** *к.* **сулыш кабу**. *[Кәҗәнең] сулуы капкан һәм сулыш алган саен борын тишекләре киңәеп-киңәеп китә иде.* И.Гази

**СУЛУ́ АЛУ** *ф. к.* **сулыш алу**. *Үсемлекләрнең тамырлары сулу ала.* А.Алиш. *[Хәлим], тәмам хәле бетеп, карга егылды. Ә бераз сулу алгач, яралының баш очына килде.* Г.Гобәй

**СУЛЫ** *с.* 1) Эченә су салынган, суы булган (савыт-саба тур.). *Сулы чиләк тар кое авызына килеп җиткәч, Гөлчирә аңа сузылды, әмма аягы таеп китеп, боз каткан кое бурасына күкрәге белән килеп төште...* Д.Каюмова. *Бу фокусны сулы стакан белән дә башкарырга мөмкин.* Р.Гарифуллин. *Иблис төпчеген җиргә салып таптады да башын сулы кисмәккә тыгып алды.* З.Мәхмүди

2) Су агып яки җыелып торган (уйсу җир һ.б.ш. тур.). *Кибәннәрне санап, яланнарны айкап, талларын иркәләп, көмеш чишмәдән чыккан сулы чокыр эченнән кояш елмаеп тора.* Д.Каюмова

3) Су үткәрү өчен хезмәт итә торган, су бирә торган. *[Егет], ишегалдында сулы кран бармы икән дип, ак алъяпкычлы кыз янына китте.* А.Шамов

4) Составында су булган, су кушылган (эчемлекләр һ.б.ш. тур.). *Стаканнарым күктер. Эчендә хикмәт күптер; Җәләй картның сулы кымызын Эчеп, эчеңне күптер.* Җыр. *Лампабыз караңгырак яна, улым. Әллә керосины сулырак инде.* Ә.Камал

5) Суга манчылган, чылатылган, юеш. *Доктор сулы чүпрәкне [авыруның] маңгаена куя.* Г.Камал. *Җамал әби чуар тавыкны кыртлавыннан биздерергә тотынды. Түшен суга тидерде. Тагын бер әмәл тапты: тавыкны сулы кычыткан белән чапты.* А.Алиш

6) Сусыл. *Алмалар бик пешкән – татлы сулы җимешләр иде.* Дәрдемәнд

**СУЛЫГУ** I *ф. к.* **сулу** I (*3 мәгъ.*). *Аның кайчандыр симез, тулы йөзе хәзер беркадәр сулыккан һәм бушап, салынып төшкән иде.* Н.Фәттах. *Беренче март көне килде: һава җылы, гөрләвекләр шарлый, тамчылар тама, кояш кышкы йокыдан сулыккан битләрне иркәли, тәнгә тормыш, яшәү дәрте сеңдерә.* Т.Галиуллин

**Сулыга бару** Торган саен ныграк сулыгу. *Көннән-көн сулыга барган Василны дуслары, Сонаның белгән кешеләре ярдәме белән, Мәскәүдә дәваланырга салалар.* Безнең гәҗит

**Сулыга башлау** Сулыгу билгеләре сизелү. *Тик Төхфәтулла сугышлардан алган җәрәхәтләреннән, картлык авыруларыннан сулыга башлаган бабай булса, Мәүлетдин көч-гайрәте ташып торган, һәрчак елмаеп, кая, тагын нинди эшегез бар дип, һәрчак эшләргә атлыгып торган, үзе сабыр холыклы егет иде.* З.Зәйнуллин

**Сулыгып бетү** Тәмам сулыгу. *Мәхәббәтсез аның шигърияте күптән сүнеп, сулып-сулыгып беткән булыр иде.* Р.Миңнуллин

**СУЛЫГУ** II *ф. к.* **сулкылдау**. *Ишетәсезме аның, сулыгып-сулыгып, Иңрәп әйткән моңлы сүзләрен?* М.Гафури. *Адәм балаларының без каеннарны нәзберек диюләре хактыр, мөгаен: минем үткәнемдә калган язлардагыча сулыгып-сулыгып елыйсым килә.* А.Әхмәтгалиева

**Сулыгып алу** Берникадәр сулыгу. *Нәкъ әнә шул мәлдә нигәдер минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды.* Мәйдан

**Сулыгып тору** Хәзерге моментта сулыгу

**СУЛЫК** *и.* Су җыелып тора, саклана торган урын (күл, буа һ.б.ш.). *Сулыклар, елгалар төрле була. Сай да – тирән дә, зур да – кечкенә дә.* Р.Хафизова. *Тиздән комплекста тагын бер ясалма сулык булдырырга уйлыйлар.* Шәһри Казан

**СУЛЫ́К-СУЛЫК** *рәв.* Сулкылдап. *Саниянең йөрәгенә нindидер үткен нәрсә килеп кадалды, кадалды да сулык-сулык сызлата...* И.Гази

**СУЛЫ́К-СУЛЫК ИТҮ** *ф.* Сулкылдау. *Кул җәрәхәтем яңарып, сулык-сулык итте.* Н.Исәнбәт

**СУЛЫ́К-СУЛЫК КИЛҮ** *ф. к.* **сулык-сулык итү**

**СУЛЫШ** *и.* 1) Организмның сулау эшчәнлеге. *Канны сафландыра, сулышны иркенәйтә торган гөрелте һаман якынлаша иде...* М.Мәһдиев. *Һәр тарафтагы иртәнге саф һава сулышларны иркенәйтә, бөтен җанны иркәли.* Г.Галиева

2) Шул эшчәнлекнең бер мәртәбә үпкәгә һава алудан гыйбарәт циклы

3) Сулаганда үпкәдән кире чыга торган һава. *Җаннар эри җанкай куенында, Ике кайнар сулыш берләшә.* К.Фатыйхова. *Әллә кайдан, йөрәк яныннан бәреп, дерелдәп чыккан кайнар сулыш аның иреннәрен пешерде.* Сөембикә

4) *күч.* Билгеле бер табигый яки иҗтимагый күренешнең сизелә, беленә башлавы, якынлашу күренеше. *Яз уяныр вакыт җитеп килә. Яз сулышын тоям җилләрдә.* Ф.Дәүләтгәрәева

◊ **Сулыш бетү** 1) *к.* **сулыш киселү**. *Үлем килми, сулыш бетмәс борын.* Ф.Бурнаш; 2) *к.* **сулыш кабу**. *Муены кысылудан сулышы бетеп мышкылдаган Торсынбай авызын ачып тирән сулыш алды.* Ф.Кәрим. **Сулыш җиңеләю** *к.* **сулыш иркенәю**. **Сулыш иркенәю** 1) Иркенләп, рәхәтләнеп сулый башлау. *Таулардан иртәләрдә хуш исләр килеп, сулышларны киңәйтә башлады.* Г.Газиз; 2) Үзеңне иркен, борчусыз хис итә башлау. *Садыйкны, сукин сын, мошенник, дип ташлагач, аның сулышы иркенәеп китте.* Ш.Камал. **Сулыш кабу** Авыр эш, кызу хәрәкәт, көчле дулкынлану һ.б.ш.дан тын алу авыраеп, еш-еш һәм өзек-өзек сулау. *Тыным буыла, сулыш капты.* Г.Бәширов. **Сулыш киңәю** *к.* **сулыш иркенәю**. **Сулыш киселү** Үлү, вафат булу. **Сулыш өзелү** *к.* **сулыш киселү**. *Сугыш, ни әйтсәң дә, сугыш инде, Холык ягы начар сугышның: Әллә кайда – ялкын уртасында Өзелүе мөмкин сулышның.* Ә.Ерикәй. **Сулыш өрү** 1) Эшкә һ.б.ш. җанлылык кертү, активлаштырып җибәрү. *Сез ул кафедрага өр-яңа бер сулыш өрдегез.* А.Расих; 2) Рухландырып, күңелне күтәреп җибәрү. *1903 елгы революциянең давылы электән изелеп килгән халыкларга яшәү сулышы өрде.* Г.Бәширов

**СУЛЫ́Ш АЛУ** *ф.* 1) Сулау, тын алу. *Тулгак авыртуының иң соңгы чигенә килеп җиткәндә, тиз-тиз сулыш алып, берничә секундка сулыш алуны туктатып торабыз һәм салмак кына сулыш чыгарабыз.* Сөембикә

2) Саф һавада йөрү, саф һава сулау; һава алмаштыру. *[Гөлзифа:] Әйдә инде, Асия. Бигрәк бөрку монда. Бер генә сулыш алып керик...* Р.Төхфәтуллин

3) Берәр эш эшләп, хәрәкәт ясап хәлсезләнүдән яки көчле дулкынлануборчылудан соң тынычланып, тигез сулый башлау; хәл алу, ял итү. *Түтеннән яшьләнгән күзләребезне уа-уа, түтен агымыннан читкәрәк киттек. Бераз сулыш алгач, тирә-ягыбызга каранырга тотындык.* Ф.Кәрим

4) Борчулардан-мәшәкатьләрдән арыну, эшләр җиңеләю; хәл, тормыш яхшыру. *Гомерем буена газап чиктем. Менә хәзер генә сулыш алырга итәм бугай.* Г.Ибраһимов

5) Гомумән иркенләү. *Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һич бер яктан сулыш алырга бирмәделәр.* Г.Тукай

6) Гомер итү, көн күрү. *Сөйли Николай заводта көн күрүен. Тормыш читенлеген: Ярлы кешегә, кая барса да, Сулыш алу җиңел түгеллеген.* Ә.Ерикәй

**СУЛЬФАТ** *и. лат. хим.* Сульфат кислотасының төрле матдәләр белән кушылуыннан барлыкка килгән тозларның гомуми атамасы; химик формуласы – $H_2SO_4$. *Сульфитлардан сульфатлар барлыкка килү*

**СУЛЬФАТЛЫ** *с.* 1) Составында сульфат булган, сульфат кушылган

2) Сульфат белән эшкәртелеп, шуның ярдәмендә табыла, ясала торган. *Сульфатлы сабын. Сульфатлы целлюлоза*

**СУЛЬФИД** *и. лат. хим.* Күкертнең төрле матдәләр белән гади кушылмаларының гомуми атамасы

**СУЛЬФИДЛЫ** *с.* Составында сульфид булган, сульфид кушылган. *Төсле металлар җитештерү өчен, гидрооксидлар белән бокситлар ---, магнезит ($MgCO_3$) һ.б. минераллар рәвешендәге бакыр, цинк, никельнең сульфидлы һәм карбонатлы рудалары хезмәт итә.* Төзү материаллары

**СУЛЬФИТ** *и. лат. хим.* Сульфит кислотасының тозы. *Сульфит кислотасы $H_2S0_3$ – эремәләрдә генә очрый торган йомшак, көчсез кислота*

**СУЛЬФИТЛЫ** *с.* 1) Составында сульфит булган, сульфит кушылган

2) Сульфит белән эшкәртелеп, шуның ярдәмендә табыла, ясала торган

**СУМ** I *и.* 1) Хәзерге Россиядә һәм төрле чорларда башка кайбер дәүләтләрдә төп акча берәмлеге булган рубльне белдергән атама

2) СССР чорында – рубльнең үзбәк, таҗик, казак һәм кыргыз телләрендәге, хәзерге вакытта Үзбәкстан һәм Кыргызстанның рәсми валюталарының атамасы

3) Әлеге кыйммәткә ия булган акча

**СУМ** II *с.* 1) *иск.* Саф, бернинди кушылмалар булмаган. *Сум тимер*

2) Тоташ йомшагыннан гына торган, сөяге һәм сеңерләре булмаган (ит тур.). *Сарыкның сум итен 1 см киңлектә, 4–5 см озынлыкта турагач, тозлап, борычлап, кызган майлы табада тиз генә кыздырып алалар.* Тәмле сәхифә

3) *күч.* Саф, гөнаһсыз. *Сум йөрәк*

**СУМА** *и.* 1) Акчалата байлык, милек. *Гадәттә Юныс бай зур сумалар белән дә бик юмарт кылана.* К.Нәҗми

2) Хак, бәя, кыйммәт. *Мидхәт берничә авыл базарыннан аз-маз сату итеп, җибәрелгән малның сумасын югалтмыйча алып кайтты.* Ф.Хөсни

3) Акчалата тулаем кыйммәт. *[Хөснулла:] – Сумасы шактый зурмыни? – Затлы әйберләр бар шул.* Ш.Камал

◊ **Сумасын чыгару** 1) Чыгымнарын каплау; 2) Гайбәтен сату

**СУМАЛА** *и. рус* 1) Ылыслы агачларның һәм кайбер үсемлекләрнең ярымкуе, һавада катып китә торган ябышкак суты; сагыз, чәер. *Чыршыда сумала юллары нараттан азрак.* Төзү материаллары

2) Катып киткәч эреми һәм җебемәүчән матдәгә әверелә торган синтетик полимер. *Алгы бүлмәдә борынга кун һәм сумала исе ярып керде.* С.Кудаш. *Шул мизгелдән соң Шайтан Чортовичның ярты гомере төзелешләрдә үтә башлады. Әнә меңнәрчә бригадалар, һәр һөнәр буенча идарәләр оеша, тәмуг гражданнары зур дәрт белән ком, сумала, алтын, цемент ташый...* Ф.Баттал. *Ташкүмер сумаласы. Синтетик сумала*

3) *күч.* Әрсез, бәйләнчек кеше

◊ **Сумала сагыз** Бәйләнчек кешегә карата. **Сумалага утыру** Гел утыру, чыгып йөрмәү

**СУМАЛАЛА́У** *ф.* Нәрсәгә дә булса сумала сылау, сөртү яки сеңдерү. *Орышып бер сүз дә әйтмәгәч, бөтенләй дә кыюланып китеп: – Сумалалап, яхшы җеп белән салырга кирәк булыр аларны! – дидем.* Ф.Яхин

**Сумалалап алу** Тиз генә, бераз гына сумалалау

**Сумалалап бетерү** Тулысынча сумалалау; бик нык сумалалау

**Сумалалап җибәрү** Бераз сумалалау

**Сумалалап кую** Алдан яки тиз арада сумалаланган итү

**Сумалалый башлау** Сумалаларга керешү

**СУМАЛАЛЫ** *с.* 1) Сумала сөртелгән яки сеңдерелгән, сумалаланган. *Бөтен тәнем чытыр-чытыр куырыла, гүя сумалалы чыбыркы минем җилкә тамырына гына төшә кебек.* Р.Төхфәтуллин. *Бер башына сумалалы чүбек урап кабызылган таяклар, һавада фырылдап, коры-сары өстенә барып төшәләр.* З.Мәхмүди

2) Сумалага буялган, пычранган. *Әти утыз ел буена үзенең сумалалы, нефтьле бармаклары белән ача-ача саргайтып, чит-читләрен «ашап бетергән» иман шартын актаргалап карады.* Г.Гобәй

**СУМАЛАНУ** *ф. иск.* Сумага ия булу, кулга акча төшерү. *[Вәли] барган саен сумаланды. Үзенең базардагы кибетен зурайтып, товарларын арттырды, төрләрен күбәйтте.* М.Гафури

**СУМАЛЫ** *с. иск.* Сумасы булган, акчага бай. *[Садыйк бай:] Сумалырак кешеләр белән әртил-мазар оештырып булса, берәр хикмәт чыгуы да ихтимал.* Ш.Камал

**СУМАСЫЗЛАНУ** *ф. иск.* Сумасыз калу, суманң, акчаң бетү. *Революциягә хәтле ул кызыл мал белән нык кына сәүдә итсә дә, революция еллары аны сыктылар, ул сумасызланды.* Г.Толымбай

**СУ́МКА** *и. рус* 1) Берәр нәрсә салып йөртү өчен чүпрәк, күн һ.б.ш.дан ясалган, гадәттә саплы янчык, букча. *Хатлар тулы күн сумкасы Иңбашына тагылган.* М.Җәлил. *Кыз ул арада үзенең юл сумкасының кесәсеннән телеграмманы чыгарып егеткә сузды.* Р.Гаязетдин

2) *анат.* Аерым әгъза яки буынны әйләндереп алган тоташтыргыч тукыма

3) *зоол.* Кайбер хайваннарның корсак астында була торган, җитлекми туган балаларын йөртү өчен хезмәт иткән букча сыман куышлык, тирән тире катлавы

**СУ́МКАЛЫ** *с.* 1) Сумкасы (*1 мәгъ.*) булган; сумка күтәргән. *Сумкалы агай безгә шулай тегесен-монысын әйткәләде дә амбар ягына китеп барды.* Н.Фәттах

2) *зоол.* Сумкасы (*3 мәгъ.*) булган. *– Димәк, монда ике сүз калды, – диде ул [карт], журналны Сәлмановка биреп. – «Турандот»ның авторы һәм сумкалы аю.* М.Мәһдиев

**СУ́МКАЛЫЛАР** *и. күпл.* Плацентар имезүчеләрдән аермалы буларак, җитлегеп бетмәгән бала тудыра, соңыннан аны җитлеккәнче сумкасында (*3 мәгъ.*) йөртә торган хайваннар инфраклассы. *Сумкалылар Австралиядә, Австралия белән янәшә утрауларда, Көньяк һәм Үзәк Америкада таралганнар.* Биология

**СУ́ММА** *и. лат.* 1) *мат.* Саннарны, зурлыкларны кушу нәтиҗәсендә килеп чыккан сан, зурлык. *Мальвина түгәрәктәге саннардан ике сан уйлаган. Ул саннарның суммасы 16 га тигез.* Математика. *Ике санның суммасы 330га тигез. Зуррак санның уң кырыйдагы нулен алып аткач, бу саннар тигезләште.* Гаилә һәм мәктәп

2) Нәрсәнең дә булса гомуми микъдары; җыйма зурлык. *1748 ел башында Сенаттан, гадәттәгечә, салымнар суммасы һәм аның түләнү сроклары күрсәтелгән хат килә.* М.Гайнетдинов

3) Акча (гадәттә зур күләм тур.). *Әгәр ике көн эчендә тиешле сумма түләнмәсә, сез инде аны [Рашатны] бу дөньядан китте, дип уйлагыз.* Ф.Садриев. *Кирәкле сумма бик тиз табылды.* Х.Ибраһим. *Кәримованың алты айдан бирле бернинди сумма кертkәне юк.* А.Нургалиева

4) Гомумән, нәрсәләрдер кушылганнан барлыкка килгән нәрсә, нәтиҗә. *Ләкин аерым берәмлекләрнең сүзлектә теркәлгән төп мәгънәләренең механик суммасы һәрвакытта да бөтен җөмләнең мәгънәсен тәшкил итә алмый.* Р.Юсупов

**СУММАР** *с.* 1) *мат.* Билгеле зурлыкларны кушу нәтиҗәсендә барлыкка килгән, шуларның гомуми суммасын тәшкил итә торган. *Әгәр күпфотонлы йотылуда фотоннарның суммар энергиясе иң югары дәрәҗә энергиясеннән артып китсә, атом ионлаша.* Фән һәм тел

2) Гомуми, барлык факторларны да исәпкә алган. *Суммар мәгълүмат. Фактларның суммар тасвирламасы*

**СУМСА** *и. фар.* Эченә ит яки йомырка белән яшелчә, җиләк-җимеш, ярма һ.б.ш. салып ясалган вак камыр ризыгы. *Бәйрәмнең беренче көнендә туйганчы сумса ашыйсың.* М.Мәһдиев. *Ашаган күп тәбикмәк, Коймак, бәлеш һәм икмәк. Чәкчәк, сумса, кош теле һәм ике табак белен. Ашаган чакта белен, Йотып җибәргән телен.* Р.Корбан

**СУМСАЧЫ** *и.* Сумса пешереп, шуның белән сату итүче кеше. *Эш белән мәш килгән сумсачы карт безне дә онытмый.* Казан утлары

**СУНАР** *и.* Тоту яки үтерү максаты белән кыргый җәнлекләрне, кошкортларны эзәрлекләү эше; ау. *Сунар вакытында аттан егылып төшүеннән соң, аның сәламәтлеге көннән-көн какшый башлый.* Р.Батулла. *Ятьмә белән чорнадылар иң беренче сунарда ук.* Зөлфәт

**СУНАРЧЫ** *и.* Сунар, ау белән шөгыльләнүче кеше; аучы. *Рәхимҗан, бик чос сунарчы кебек, хикәяләвен белде: – Иң әүвәл аның кыш уздыра торган өнен табасың.* М.Хәсәнов. *Сунарчы капкынга эләккән бүрегә ничек карый икән?* Х.Камалов

**СУНАРЧЫЛЫК** *и.* Сунарчы һөнәре, шөгыле; аучылык. *Авыл кешеләре башлыча сунарчылык, балыкчылык белән көн күрәләр.* Т.Нәбиуллин

**СУП-** *кис.* Кайбер сыйфатлардан артыклык дәрәҗәсе ясый торган кисәкчә. *Мамык юрган, Кат-кат сырган, Үзе суп-суык.* Табышмак

**СУПАЮ** *ф. диал.* Чырайга канәгатьсезлек, ризасызлык төсмере чыгару; төшенкелек кебек күңелсез хисләргә бирелү

**Супаеп йөрү** Озак вакыт супайган булу. *Бу ел халык гадәттәге төсле түгел. Барысы да супаеп йөри, күп сөйләшми иде.* С.Әдһәмова

**Супаеп тору** Хәзерге моментта супайган булу

**СУ́ПЕР-** *гр.* 1) Кушма сүзләрнең «икенчел, өстәмә» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәге (мәс., *суперстрат*)

2) Кушма сүзләрнең «төп, баш» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәге (мәс., *суперинтендант*)

3) Кушма сүзләрнең «бик, нык, үтә; иң югары сыйфатлы, иң көчле, иң өстен» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәге. *Ул хәзер «универсаль» генә түгел, «супeруниверсаль» бәйлеккә әйләнде.* Х.Сарьян. *Үзләрен суперзаманча фикерләүчеләр дип фаразлаучы мондый агай-эне безнең әдипләрне чынлыкта --- яңарышның асылын аңлый алмавын күрсәтә.* Ф.Мусин

**СУПЕРМА́РКЕТ** *и. ингл.* Көн дә кулланыла торган товарлар (гадәттә азык-төлек, хуҗалык әйберләре һ.б.ш.лар) сатыла торган зур универсаль кибет. *Супермаркеттан сиңа тәмле-тәмле әйберләр алып кайттым.* З.Хәким

**СУПЕРМОДЕЛЬ** *и. ингл.* Дөньякүләм танылган, күп акча алып эшләүче модель. «*Супермодель–2012» конкурсында балалар театр модасы мәктәпләренә һәм студияләргә йөрүче 150 бала катнашты.* Сабантуй

**СУПЕРФОСФАТ** *и. лат. махс.* Фосфорлы химик ашлама; соры төстәге порошок

**СУППЛЕТИВ** I *и. лат.* Сүз парадигмасының башка нигездән ясалган формасы

**СУППЛЕТИВ** II *с.* Супплетив (I) булган; супплетивка хас. *Супплетив парлар. Супплетив форма*

**СУППЛЕТИВИЗМ** *и. лат. лингв.* Бер үк лексик мәгънәгә ия булган сүзләрнең аерым грамматик формалары төрле тамырдан ясалу күренеше (мәс., берлек санда *син*, күплек санда *сез – синнәр* түгел)

**СУР** *и. гар.* 1) *иск.* Мөгез быргы

2) *дини* Кыямәт көнендә Исрафил фәрештә өрәчәк быргы. *Кыямәт көнендә Исрафил сурын өргәч, адәмнәр, терелеп, кабер өстендә җитмеш ел хәйран булып утырган кебек, Аркадия бакчасында (Әхмәт бай йортына каршы) эскәмияләрдә эшсез хәйран булып утыручылар бу ел да күп иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Бер көн, дигән, сур өрерләр, һәм мәетләр кубарлар. Ничек дип җавап бирерләр? – Гөнаһларын сорарлар.* М.Максуд

**СУРАЮ** *ф. сир. к.* **серәю**. *Күз алдымда торма, икенде күләгәсе кебек сураеп.* Т.Миңнуллин

**СУРӘТ** *и. гар.* 1) Рәсем, портрет. *Бөек Җиңү бәйрәме алдыннан Мәскәү урамнарына Сталинның сурәтен урнаштыру – әхлаксызлык.* Ватаным Татарстан

2) Форма. *[Кояштагы] таплар төрле сурәттә вә зурлыкта булалар.* Ф.Әмирхан

3) Кыяфәт, килеш-килбәт. *Сурәте бик матур бер кыз, имеш: күзләре ут кебек янып тора, чәчләре кара болыт кебек актарылып, ташу дулкыннары кебек дулкынланып торалар, имеш...* Ә.Фәйзи

4) *иск.* Әдәби образ

**СУРӘТЛӘМӘ** *и.* Сурәтләр, образлар ярдәмендә бирелгән тасвирлама. *[Кайбер] мәкальләрдә ниндидә булса шигъри күренешләр, кинаяле сурәтләмәләр күренми, алар, кыска-кыска гына итеп, кешегә турыдан-туры берәр тәҗрибә, акыл яки киңәш бирәләр.* Н.Исәнбәт

**СУРӘТЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **сурәтләү**. *Ташбасмадагы Диюнең кул бармаклары карт чинар агачының ботакларына охшатылып сурәтләнсә, бүтән басмалардагы Диюнеке адәм гәүдәсе кадәр итеп бирелә.* Ф.Яхин. *Укучы сөйләгән вакытта, кечкенә Габдулла, әнисе, Шәрифә карчык, Зиннәтулла бабай һ.б. сурәтләнгән слайдлар күрсәтелә.* А.Хөснетдинова

**СУРӘТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Төрле сурәт яки сурәтләр белән бизәү. *Стеналарны сурәтләү*

2) Тасвирлау. *Иске карашлар һәм реакцион фикерләр утравына әйләнгән «Печән базары»нда --- Г.Тукай «Көфер почмагы каһарманнары»ның милләтне юкка чыгару чигенә китереп җиткерә язган гамәлләрен сурәтли.* Ф.Ханнанова. --- *Исхакый аның хис-кичерешләргә тирән, бай, йөрәк тавышы ишетелгән, сурәтләү чаралары, образлары мул булган камил, матур, төзек күңел шигырьләрен һәм гражданлык лирикасын күздә тота.* Т.Гыйлаҗев

**СУРӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Сурәтләр (*1, 2 мәгъ.*) төшерелгән, сурәтләр белән бизәлгән. *Җепне сатып алуга ук нинди сурәтле кофта бәйләячәген белә.* Авыл офыклары

2) Билгеле рәвештәге, кыяфәттәге, формадагы

3) Сурәт, образлар белән белдерелгән; сурәтләрдә гәүдәләнеш тапкан

**2.** *рәв. мәгъ.* Конкрет сурәтләр ярдәмендә, ачык, аңларлык итеп. --- *фикерхисне укучыга сурәтле итеп җиткерү өчен, халык иҗаты символикасыннан һәм әдәбият-сәнгатьтәге шартлы алымнардан мул файдалана.* Р.Фәйзуллин

**СУРӘТТӘ** *рәв.* **1.** Билгеле рәвештә, хәлдә. *Күңелсез генә сурәттә чәй эчеп тәмам иткәч, Шәриф дәхи эш эзләп чыгып китте.* М.Гафури

**2.** *терк. мәгъ.* Тәкъдирдә, билгеле очракта, хәлдә. *Атасы аннан куып чыгарган сурәттә дә, Нәфисә барыбер үкенмәгән булыр иде.* Г.Бәширов

**СУРӘТЧЕ** *и. сөйл.* Сурәт (*1, 2 мәгъ.*) ясаучы; скульптор яки рәссам. *[Кошның] койрыгындагы күз-күз түгәрәк бизәкләре бик оста сурәтче кулы белән ясап куйган төсле.* Ә.Фәйзи

**СУРГУЧ** *и. к.* **сургыч**. *«Технологиядән берничә кәлимә» дигән рубрикада крахмалны куллану очраклары, сургуч, одеколон, лак җитештерү тарихы һәм ысуллары күрсәтелгән ---.* Р.Нуруллина

**СУРГУЧЛА́У** *ф. к.* **сургычлау**. *Җәмил төргәкне сургучлап, үзенең кесәсендә генә йөртә торган җиз пичәтне сукты.* Г.Гобәй

**СУРГУЧЛЫ** *с. к.* **сургычлы**. *Кабинет хуҗасы Артёмның кнопкалы хәнҗәрен сорап алды һәм сургучлы пичәт сугылган шнурларны кисеп җибәрде ---.* Р.Мирхәйдәров

**СУРГЫЧ** *и.* **1.** Нәрсәне дә булса пичәтләп ябыштыру, шешә башларына кою һ.б.ш. өчен кулланыла торган, тиз эреп, тиз катучан сумаласыман матдә. *Шешә башларыннан кызыл сургычлар купты, шешәнең стаканга бәрелеп чык-чык килүе ишетелеп торды.* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* Шул матдәдән гыйбарәт булган. *Өлкәнрәк абый, шешәне ачар алдыннан, --- пәке белән сургыч бөкене кырып төшерде.* Ә.Баян. *Микулай*

*өстәлгә каяндыр бер сургыч башлы «малай»ны да чыгарып куйды.* З.Мәхмүди

**СУРГЫЧЛА́У** *ф.* Сургыч белән беркетү, сургыч ябыштыру

**Сургычлап кую** Тиз арада яки алдан сургычлау. *Президент коммунистлар партиясен япкач, Бутаушев әфәнде парторг бүлмәсен сургычлап куйды.* Казан утлары

**Сургычлый башлау** Сургычларга тотыну

**СУРГЫЧЛЫ** *с.* Сургыч белән беркетелгән, ябыштырылган, сургычланган. *Әрҗәнең шакмаклы ояларында башлары сургычлы шешәләр ялтырап утыра иде.* Н.Фәттах. *Минзәки ак шешәнең сургычлы бөкесен ачканда гына, кияү балакай Сафуан да ишектән керде.* З.Мәхмүди

**СУРДОПЕДАГОГ** *к. махс.* Сурдопедагогика белгече. *Протез куйдырганнан соң да, сурдопедагогларга, ата-аналарга баланың сөйләм телен җайга салу өчен шактый тырышырга туры киләчәк әле.* Ватаным Татарстан

**СУРДОПЕДАГО́ГИКА** *и. лат. махс.* Начар ишетә яки бөтенләй ишетми торган саңгырау балаларны һәм үсмерләрне укыту-тәрбияләү педагогикасы. *Сурдопедагогика, тифлопедагогика, логопедия – шулай ук аваз теле белән бәйле.* Ф.Сафиуллина

**СУ́РИК** *и. лат.* 1) Составында кургаш булган минерал

2) Гадәттә бүтән буяуларга, замазкага һ.б.ш. кушып кулланыла торган саргылт кызыл яки көрән кызыл буяу. *Икенче көнне, пароходны тутыктан арындырып бетергәч, шәрә металлга сурик салырга керештек.* М. Юныс

**СУРИКАТ** *и. лат. зоол.* Мангустчалар семьялыгыннан Көньяк Африка чүлләрендә таралган, озаклап арткы тәпиләрендә басып тора алган, колонияләр оештырып яши торган имезүче хайван. *Араларында сурикат, тиен, төлке, әрлән, попугай, куян, африка керпесе, ташбакалар булган.* Казан утлары

**СУ́РИКЛЫ** *с.* Составында сурик (*2 мәгъ.*) булган, сурик кушып ясаган. *Суриклы шпаклёвка*

**СУ́РИЯЛЕ** *и.* Сүриядә яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган кеше. *«Мәгыйшәт юллары» (Казан, 1908), сурияле гарәп язучысы Никола Хаддатның «Сөймәк вә өйләнмәк», «Өйләнмәк вә үкенмәк» әсәрләре (Оренбург, 1909 ел). Болары гарәп дөньясына бәйле рәвештә туган, шул телдән тәрҗемә ителгән.* Л.Хәмидуллин

**СУРРОГАТ** *с. ингл.* **1.** 1) Табигый ризыкны, товарны һ.б.ш.ларны алмаштыра, ләкин сыйфаты ягыннан өлешчә генә оригиналга охшаган ясалма продукт; эрзац. *Ларёклардан алган суррогат эчеп, эчәкләр өзелә инде.* Ф.Яруллин. *«Коньяк» дигәнегез – техник спирттан ясалган бер суррогат, коньякның анда эзе дә юк иде.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Гомумән берәр нәрсәне алмаштыра ала дип күзалланган башка нәрсә. *Әмма нишләтәсең, яңа татарлар заманы, чын татар теле, аның нәфислеге, көче, аһәңе театрлардан китеп бара, аларны суррогат алыштыра.* Т.Миңнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Ясалма, ялган (ризык, товар һ.б.ш.лар тур.). *--- соңгы вакытта медицина хезмәткәрләренә суррогат алкоголь куллануның зарарлы нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләр саны арта бара.* Мәдәни җомга

**СУРЫГУ** *ф.* 1) Берникадәр кибү, сарыга төшү (аяк асты һ.б.ш. тур.). *Юл сурыкканга күрә, йөрү җиңел булды.* М.Гафури

2) *күч.* Бераз ябыгу, тартылу, суырылу. *Бөек җиңү хөрмәтенә үткәрелгән тантанага кичә генә сбордан азмыкүпме куәтләнеп, бераз сурыгып кайткан лейтенант Билалов башка командирларише өр-яңа парад формасыннан чыкты.* С.Шәрипов

3) *күч.* Киму, саегу. *Ул чыгып киткәч, мәҗлеснең «пары» суына башлый, илһамлы сүз дәрте сурыга, утырдашларның кызыгы бетә.* М.Галиев

**Сурыга бару** Әкренләп сурыгу. *Инде шигърияттә глобальлек чире: Җир шарын иңгә утыртып яисә учка алып, үзең күтәрә алмаслык «олы гамьгә» чумулар сурыгып бара иде.* М.Галиев

**Сурыга башлау** Сурыгуы сизелү

**Сурыга төшү** Бераз сурыгу; тагын да сурыгу

**Сурыгып китү** Сизелерлек сурыгу

**СУСАКЛАГЫЧ** *и.* Махсус су саклау өчен ясалган гидротехник корылма, зур сулык. *Бездә бик зур сусаклагыч бар.* А.Хәсәнов

**СУСАР** *и. зоол.* Сусарсыманнар семьялыгыннан озынча гәүдәле, очлы борынлы, кыйммәтле мехы өчен аулана яки үрчетелә торган ерткыч җәнлек; *русчасы:* **куница**. *Балаларына бурсык, сусар, кама да тотып кайткалый.* А.Хәсәнов

**СУСА́РСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Имезүче ерткыч хайваннарның сусар, бурсык, кама кебек илледән артык төрен берләштергән семьялыгы

**СУСАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сусау**. *Урманнарда үскән пар каенны Урамына язын күчергән, Сусатмаган, инешләрдән ташып, Кушуч белән сулар эчергән.* Ш.Галиев

2) *з.-сыз* Эчәсе килү. *Бик эссе ич бүген, сусата.* Т.Әйди

**СУСА́У** *ф.* 1) Бик нык эчәсе килү; тамак кибү. *«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым», – дидем.* Г.Тукай

2) Дымга, суга, яңгырга мохтаҗ булу (үсемлекләр тур.). *Яңгыр бу көнне дымга сусаган туфракны, үсемлекләрне суга туендырды, аларга яшәү көче бирде.* Сабантуй

3) *күч.* Берәр нәрсәгә ихтыяҗ булу, шуны бик теләү, шуңа омтылу. *Октябрьга кадәрге классик хикәя-новеллалары халыкның моң-зары, азатлыкка сусау хисләре, якты бәхет турында хыяллары белән тулы.* Х.Хәйри. *Әлеге җыентыкның Финляндиядә басылып чыгуы да Тукай иҗатына сусау, аны сагыну, билгеле иҗтимагый шартларда килеп туган рухи ярлылыкны тутыру була.* Л.Гобәйдуллин

**Сусап бетү** Тәмам, бик нык сусау. *– Зәйтүнәм, син безне чәй белән сыйла әле, бу челләдән тәмам сусап беттек, – диде Илбарис.* С.Сабиров

**Сусап йөрү** Күптәннән бирле сусаган хәлдә булу. *Авыл җирендә, урын өстендә яткан килеш шагыйрь булырга җыенган кешегә язучылардан килгән һәр хат – эссе ком чүлендә бер тамчы*

*суга сусап йөргәндә, челтерәп аккан чишмә табу белән бер*. Ф.Яруллин. *«Нигә ул сиңа шәһәр фатиры? Бирегез аптырап, сусап йөргән бирәр бәндәгә», – диләр*. Д.Салихов

**Сусап китү** *к.* **сусый башлау**. *Төшке аш вакыты җитүгә, рестораннарга, кафеларга йөгерәбез; эшебез тыгызрак чакта, «биг-ланч»лар, «биг-мак»лар белән чикләнәбез; сусап китсәк, «пепси» эчәбез*. М.Кәбиров

**Сусап тору** Сусау хәлендә булу. *Фәнияр, көчле гипнозга ия булган кеше шикелле, үзенә килүчеләрне тиз генә җибәрми. Ул чын-чынлап кешеләргә сусап тора*. Ф.Яруллин. *Ул тартылу шундый көчле: янап торган куркуларны да җиңә. Җаны хаклыкны белергә сусап тора*. Х.Камалов

**Сусап яту** *сөйл. к.* **сусап тору**. *Сип әле, сип, энем! Корып-кибеп, суга сусап ятмасыннар*. Н.Каштанов

**Сусый бару** Торган саен ныграк сусау. --- *сурәтле фикерләвенең шигърият үрләренә күтәрелә барган саен халыкчан, милли нигезләргә сусый баруы, таяныч ноктасын шуннан эзләве коткара*. Казан утлары

**Сусый башлау** Сусау сизү. *Ялгызлыкка көннән-көн ныграк сусый башлады ул*. Казан утлары

**СУСЫЗ** *с.* **1.** 1) Эчендә суы булмаган, су салынмаган (төрле савыт-саба тур.). --- *ул чәчәкне сусыз вазага төртте, күчтәнәч салынган пакетны исә бер идәнгә, бер өстәлгә куеп маташты*. Н.Гыйматдинова

2) Суы югалган, суы беткән, кипкән (төрле сулыклар тур.). *Сусыз күлдән су сал иләккә, Тутыр аны төпсез чиләккә*. Т.Миңнуллин

3) Суы, дымы булмаган, судан, дымнан мәхрүм (төрле җирләр, бигрәк тә чүлләр тур.). *Сусыз дала, коры сахраларның Өермәле була ла, ах, дусларым, җилләре; Һәркемнең лә үзенә якын була Туып та ла үскән, ах, дусларым, илләре*. Җыр. *Заһидуллин сусыз, коры Төньяк Маньчжурия далаларын үтә*. Т.Нәҗмиев

4) Суүткәргече булмаган, су белән тәэмин итү челтәренә тоташмаган. *Бөтенләй сусыз авыллар була: анда кое белән генә көн күрәләр*. М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Су булмаган хәлдә. *Дөнья утсыз, сусыз, һавасыз тора алмый шул*. Ф.Яруллин

2) Су эчмичә, суга мохтаҗ булып. *Кави Нәҗми салкын карцерда ризыксыз, сусыз тәүлектән артык ята*. З.Зәйнуллин // Су бирмичә, эчәргә бирмичә. *Мине милиция бүлегендә ифрат каты кыйнадылар. Кулларымнан түшәмгә элеп куеп, сусыз интектерделәр*. Т.Галиуллин

3) Су салмыйча, су кулланмыйча. *Ризыкны сусыз пешерү*

4) Сугармыйча, су сипмичә; суга җибәрмичә. *Ике капкачлы моллюскларны теләсә нинди капчыкта яки тартмада сусыз да тотып була*. Яшь натуралистларга

**СУСЫЗЛЫК** *и.* 1) Сусыз булу хәле

2) Суга, дымга ихтыяҗ; корылык. *Россиянең барлык шәһәрләрендә һәм барлык урыннарында ачлык, сусызлыктан гаҗиз итте*. Г.Тукай

3) Бик нык сусау хәле. *Әмма баягы ятим кошчыклар, ачлык, сусызлыкта тыныч утыра алмыйча, берзаман Төлкенең авыз төбенә үк егылып төштеләр*. Г.Тукай

**СУСЫЛ** *с.* Составында су чагыштырмача күп булган, эчендә суы күп булган (үсемлек, мал азыгы һ.б.ш. тур.). *Казаклар кышны шунда уздырып, бу вакытта инде сусыл үлән белән капланган киң далага – терлек көтү өчен җәйләүләргә чыгалар*. З.Рәсүлева. *Ә инеш башланган якта Каенлы елга, Балан елгасы, Үгез елгасы дип аталган, язгы ташуда су белән тулып, ә җәен кибеп, сусыл үлән белән каплана торган чәчәкле, җиләкле болыннар җәелеп ята*. Ә.Галиев

**СУСЫЛЛАНУ** *ф.* Сусылга әйләнү. *Әгәр болында кеше күзеннән яшеренеп сусылланып пешкән җир җиләгe тапсаң, авыз итмичә түзәрсеңме?* К.Кәримов

**Сусыллана бару** Акрынлап сусыллану

**Сусыллана төшү** Берникадәр сусыллану

**Сусылланып бетү** Тәмам, бик нык сусыллану

**Сусылланып тору** Сусыл хәлдә булу. *Алар, буялган кебек, ничектер сусылланып тора*. Ф.Зариф

**СУСЫЛЛЫК** *и.* Сусыл булу үзлеге һәм хәле. *Нәтиҗәдә, мал азыгы бозылмый, сусыллыгын югалтмый*. Кызыл таң

**СУСЫН** I *и. монг.* 1) Тамак кибү, эчәсе килү тойгысы, шундый халәт. *Аждаһаның, эчкән саен, сусыны кабара, ди*. Ә.Фәйзи

2) Эчәсе килүне баса торган нәрсә; эчемлек. *«Юлчыга сусын бирү – юсын» дигән мәкальдә юсын турыдан-туры «тәртип, кагыйдә, закон» дигән мәгънәләргә туры килә*. Н.Фәттах

**СУСЫН** II *и. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан кылыч сыман эре кыяклы, шәмәхә, күк яки сары төстәге эре чәчәкле күпьеллык үсемлек; ирис. *Ясыйм ал кашкарыйлар, Шәп-шәмәхә сусыннар*. В.Хәйруллина

**СУТ** *и.* 1) Үсемлек, җимеш һ.б.ш.ларның күзәнәкләрендә була торган сыекча, су; үлән сүле. *Мистицизм, ни генә дисәк тә, ул әле үлән суты кебек, кешенең тамырлары буйлап хәрәкәт иткән яшәеш, тереклек билгесе сыман да түгелме?* Ф.Яхин

2) *күч.* Физик һәм рухи көч, егәр; мөмкинлекләр. *Шактый яшәү сутын суырган кара диндарлыкка, дини фанатизмга ул беренче кискен мөнәсәбәтен кайчан белдерә?* З.Мансуров

**СУТЕНЁР** *и. фр.* Фахишәлекне кәсеп буларак оештыручы кеше

**СУТЕНЁРЛЫК** *и.* Сутенёр кәсебе

**СУТКАК** *и. диал.* Сутлы балчык. *Яланбаш булганга чәчләре белән бергә йөзләре дә, хәтта колак яфракларына кадәр, күл төбенең чем кара торфлы суткак пычрагы белән капланып каткан иде*. Ш.Маннур

**СУТЛЫ** *с.* 1) Юеш, сулы һәм берникадәр лайлалы (балчык тур.). *Исмәгыйль белән Кәрим, су буена төшкәч, җиңнәрен, ыштан балакларын сызганып, ташу суы казыган чокырга керделәр дә аннан йомшак сутлы балчык алырга керештеләр*. М.Галәү

2) Чи, дымлы. *Яз бөтен нәрсәгә тереклек сулышы өрде. Урманда, болыннарда хәзер яфрак, яшь үрентеләр, сутлы кайры, ашарга ярарлык үлән тамырлары, суда балык бар ---* . М.Галәү

3) Сусыл. *Сутлы алма*

**СУ́ҮСЕМ** *и. бот.* Тамыр, сабак һәм яфракка аерылмаган, түбән төзелешле су үсемлеге; *русчасы:* **водоросль**. *Уртадан без барабыз, яр буйлары камышлар, суүсемнәр белән тулган. Камыш тамырын балыклар шытыр-шытыр кимерә.* Н.Әхмәдиев

**СУФИ** *и. гар.* **1.** Суфичылык тарафдары; исламның суфичылык агымын тотучы мөселман. *Буш суфи нигә ярый дин белмәгәч, Борнына диннең исе дә кермәгәч?* Г.Тукай. *Бу нәселдән зур шәехләр, суфилар, гыйлем ияләре чыккан.* Ф.Бәйрәмова

**2.** *с. мәгъ.* Суфичылык карашларындагы, шуны алга сөрә, пропагандалый торган (әдәби юнәлеш, язучы һ.б.ш. тур.). *Суфи шагыйрьләрдә замана, Җир тормышы кешене, халыкны, рухны юкка чыгаручы, җимерүче итеп бирелсә, Г.Тукай монда ишаннарны, ягъни суфиларның үзләрен гаепли.* Ф.Яхин

**СУФИЛАНУ** *ф.* Суфи булып күренергә тырышу, изге булып кылану. *Бик ашыйсы килсә дә һәм барса да ачтан үлеп, Сузыла ул [Мияубикә] ашка ашыкмый, бик суфиланган булып.* Г.Тукай

**Суфилана башлау** Суфиланырга керешү

**Суфиланып бетү** Тәмам, бик нык суфилану

**Суфиланып тору** Хәзерге моментта суфилану

**СУФИЛЫК** *и.* 1) Суфига хас сыйфатлар; суфи булу хәле. *[Раил Садриев:] Уен-көлке тамашачыны боза, дип кем әйтә?! Юмор ул – фәлсәфә! Без үзебез Хуҗа Насретдинне юләргә чыгарып, аның зирәклеген, суфилыгын оныттырабыз.* Идел

2) *к.* **суфичылык**. *Безнең әдәбиятның борынгы ярым гарәпчә, ярым госманлы, чыгтайча, борынгы төрки телле динлек, суфилык, ишанлык белән тулы әдәбияты – феодализм калдыгының турыдан-туры җимешләре.* Г.Ибраһимов

**СУФИ́ ЧИКЕРТКӘ** *и. зоол.* Тропик һәм субтропикларда яшәүче, алгы аяклары азыкны тотар өчен җайлашкан, канатлы эре ерткыч бөҗәк; *русчасы:* **богомол**. *Әлегә суфи чикерткәләрнең саны күп түгел, һәм моны очраклы күренеш дип әйтеп була.* Шәһри Казан

**СУФИЧЫЛ** *с.* Суфичылыкка бәйле булган; шуны яклый торган. *Суфичыл карашлы булу гына, мәсәлән, Таҗетдин Ялчыголга тарихи әсәр язуга комачаулык итмәгән.* Казан утлары

**СУФИЧЫЛЫК** *и.* Ислам динендә зикер-тәсбих, фикерләү кебек рухны үстерүгә юнәлгән күнегүләр аша Аллаһның табигатен акыл белән түгел, хис аркылы аңлауга ирешеп була, дип раслый торган дини һәм фәлсәфи агым; тәсаувыф. *Тукай суфичылыкны инкяр итә.* Ф.Яхин

**СУФЛЁР** *и. фр.* Театрда тамаша яки репетиция вакытында актёрның репликаларын әйтеп торучы сәхнә хезмәткәре. *Суфлёр кычкырып-кычкырып укый, кемдер аның артыннан декламацияли.* А.Алиш. *Партком бүлмәсенең тәрәзә артына килеп утырган суфлёр, бу эштә яңа кеше буларак, бер генә сүзне дә төшереп калдырмыйча, пьесаны рәттән укып бара.* Сәхнә

**СУФЛЁРЛЫК** *и.* Суфлёр хезмәте, суфлёр вазифасы. *Хәер, минем өстә тагын суфлёрлык кала, мин – бик әйбәт суфлёр, әмма үзем, әллә килештермәгәнгә, әллә кулымнан килмәгәнгә күрә, бервакытта да роль алмый идем.* Ә.Еники

**СУФФИКС** *и. лат. лингв.* Сүзнең тамыры белән төрләндергеч кушымчасы арасында тора торган ясагыч кушымча. *Рус телендә исемнәр приставка һәм суффикс ярдәмендә, ә татар телендә сүз тамыр плюс кушымчадан ясала.* Татар теле

**СУ́ЧИСТАРТКЫЧ** *и.* Махсус су чистарту җайланмасы

**СУЧЫ** *и.* Су ташу, су белән тәэмин итү эшендә эшләүче кеше. *Очучылар, космонавтлар, галимнәр, врачлар булабыз, фәлән эшлибез, төгән кылабыз дип укып килдек тә, мәктәп бинасыннан чыгуга ук тормыш хакыйкате белән очраштык: безнең күбебезгә кондукторлар, лифтёрлар, монтёрлар, пешекчеләр, сучылар булып эшләргә туры килә икән.* А.Гыйләҗев

**СУ́ШИ** *и. яп.* Башлыча дөге һәм диңгез продуктларыннан ясала торган милли япон ризыгы. *Интернетта һәм матбугатта суши һәм ролл тәкъдим итүче реклама күбәйде.* Кызыл таң

**СУ́ШИ-БАР** *и. яп.-ингл.* Төп ризыгы суши булган бар, кафе. *Дөрес, кайчагында, кызларга ияреп, мин дә суши-барга яки берәр пиццерияга, кинотеатрга барыштырам.* А.Әхмәтгалиева

**СУШИ́ЛКА** *и. рус* Башлыча ашлык киптерү өчен махсус җиһазланган урын яки машина, аппарат һ.б.ш. *Амбарларга, сушилкаларга вак-төяк төзәтүләр кирәк булачак.* Т.Гыйззәт. *Ни арада узадыр: әле амбарда, әле сушилкада, әле идарәдә – Хәмит абзый берьюлы бөтен җирдә була иде.* М.Мәһдиев

**СУЫК** *с.* **1.** 1) Чагыштырмача түбән температуралы; *киресе:* **җылы**. *Сугышның каты суык көннәрендә, Шулай ук җәйге төннәрендә Азмы-күпме чыныктыгыз.* Н.Габделкәримова. *– Әтиегезгә нәрсә, рәхәт аңа: җылы толыпка төренеп кенә, чанага кырын ятып кына, кырга салам ташырга китте. Ә мин менә, кара буранда, суык абзарда, бура кебек сыерны көчкә савып кердем, уф Алла! – диде әниләре, авыр көрсенеп.* Б.Ислам

2) Кайнарлыгы яки җылылыгы кимегән яки тулысынча беткән; суынган, салкын (аш-су тур.). *Мулла бабай, күзен йомып, бераз уйланып торды, мәгәр белмәгәнен сиздермәде: – Гарәпләр юләр түгел, суык аш ашамыйлар! – дип тамак кырды.* Б.Ислам

3) Җылылык чыгармый, җылылык чыганагы була алмый яки җылылыгы сизелми торган (төрле җисемнәр, нурлар һ.б.ш. тур.). *Суык мич. Суык йолдызлар*

4) *күч.* Хискә бирелмәүчән, салкын канлы; каты, кырыс табигатьле (кеше тур.)

5) Ягымлы булмаган, кырыс, коры, артык рәсми, тәкәббер (мөгамәлә, караш һ.б.ш. тур.). *Ризван абый буйсынды, аннары кабат калкынды: – Син!.. Син!.. Син!.. – Сүзләре хисләреннән суыграк чыктылар.* Ф.Яхин. *Мәрҗани хәзрәт озын буйлы, тулык гәүдәле, суык чырайлы, вәкарьле, гаять мәһабәт, мәҗлесләрдә аз сүзле...* Гасырлар авазы

6) *күч.* Рәхимсез, аяусыз, битараф. *Өмид күгемдәге йолдыз атылды, Суык*

*тәкъдир минем күңлем катырды.* З.Бурнашева

**2.** *и. мәгъ.* Салкынлык; түбән температура; салкын һава. *Аерата зәһәр, зәмһәрир суыклары белән җан ияләренең теңкәсен корыткан кышлар...* А.Гыйләҗев. *Дивизия батальоннары, полклары, ноябрь суыкларында тишек итекләр, солдат ботинкалары белән Сивашны кичеп чыгып, акларның чәнечкеле чыбык белән өч кат уратып алынган окопларына, пулемётларына ташланалар.* З.Зәйнуллин

◊ **Суык алдыру** Берәү суык тәэсирендә авырып китү. *Гүзәл урамда озак йөреп суык алдырган.* **Суык алу** Берәүгә суык тәэсир итеп, аны авыруга китерү. *Урамда озак йөргәнгә, Гүзәлне суык алган.* **Суык аяк** Гел җиңел кәсеп кенә эзләп йөрүче кеше, зимагур, сукбай. *Берьюлы бернича тавыш олаучыга юнәлде: – Әй, суык аяк, көнең шуңа калдымыни инде? – Чыптаң белән бергә бала сата башладыңмыни?* Ә.Фәйзи. *Элек, без яшь чакта ук әле, ул якларга рәтле кеше аяк басмады. Диңгез матурлыгы, балык, фәлән-фәсмәтән дип юкка хыялланып йөрүче төрле суык аяк зимагурлар гына алданып китәләр һәм, ник барганнарына үкенеп, тәмам өтелеп кайта торганнар иде.* С.Сабиров. **Суык канлы** *к.* **салкын канлы**. *Йосыфҗан – акыллы, суык канлы, нечкә аңлы, зирәк-тырыш, ләкин гаҗәп эгоист табигатьле бер егет.* Г.Ибраһимов. **Суык йөгерү** Тәнгә суык үтү, суык була башлау, туңа башлау. *Антоновның аркасына суык йөгерде.* З.Зәйнуллин. **Суык тидерү** *к.* **суык алдыру**. **Суык тию** Суык тәэсирендә авырып китү, чирли башлау. *Корбангали карт бүлмә астындагы куышларны төзәтә-төзәтә суык тидереп үлгән.* Ш.Камал. *Хәрби манёврлар вакытында пушкасы, атлары астында боз ватылып, елгага чумган әтиләре Иннокентий, суык тидереп, үпкәләре шешеп, ун көн дигәндә бу дөньядан китеп бара.* З.Зәйнуллин

**СУЫ́К БАБАЙ** *и.* Кыш бабай. *Суык бабай, кил безгә Яңа ел бәйрәменә.* М.Җәлил. *Суык бабаем да бәйрәм көтә, Әзерләнә кышкы бәйрәмгә.* Ф.Дәүләтгәрәева

**СУЫКЛАНУ** *ф. к.* **суыну**. *Һава суыкланып, куәтле җилләр исә башлады.* Ф.Әмирхан. *Кайнарланып нәрсә булдырдык та, Суыкланып нәрсә югалтканың?* Ф.Яхин

**Суыклана бару** Торган саен суыклану. *Әңгәмә, ниһаять, үзенең кабыгын сала башлады, һәм әле генә шундый тыныч яңгыраган басынкы тавыш корылана, суыклана барды.* К.Нәҗми

**Суыклана башлау** Суыклануга таба үзгәрү

**Суыклана төшү** Берникадәр суыклану; тагын да суыклану

**Суыкланып бетү** Тәмам, бик нык суыну

**Суыкланып калу** Суык хәлгә килү. *Син киттең... Бөтен дөнья суыкланып калды.* Ф.Яхин

**Суыкланып китү** Кинәт суыклану. *Көн суыкланып китеп кыса башлаганчы, урман араларында юешлек сизелә башлаганчы ук, шунда калды [Шәмси].* Г.Исхакый

**СУЫКЛАТУ** *ф. к.* **суыту** (*1, 2 мәгъ.*). *– Җитәр инде. Кышның көне күп суыклатты, – ди, җәелеп агып ята торган елга әйтә. – Инде торып эшкә ябышырга вакыт.* С.Җәлал

**СУЫКЛЫК** *и.* 1) Җылы белән чагыштырганда суык булу хәле; түбән температура. *[Надир] Сүзне икенчегә борыр өчен генә булса да әйтеп куйды: «Әй суыклыгы быел кышның!»* Ф.Дәүләтгәрәева

2) *күч.* Кемне дә булса ошатмауга, яратмауга нигезләнгән мөнәсәбәт; кырыслык, корылык. *Мөгамәләдәге суыклык*

3) *күч.* Авырлык, кырыслык, аяусызлык (шартлар тур.). *Әллә еллар суыклыгы өшетә иде, Әллә җанның кызулыгы саран иде...* Ф.Яхин

**СУЫКСУ** *ф.* Үзеңне җылылык җитмәгән кебек хис итү, берникадәр салкынлык тоеп, азрак туңып тору

**Суыксып китү** Берникадәр, кинәт суыксу. *Бер куанам, Бер оялам, Бер суыксып китәм, Бер янам.* Ш.Маннур. *Төнге салкын чыкта суыксып киткән табигать иртәнге кояшның беренче нурларын тою сөенечен яшерә алмый елмая кебек иде.* Бөгелмә авазы

**Суыксып тору** Хәзерге моментта суыксу. *Ул тәне суыксып торудан зарланып алды, көзен-кышын өстеннән төшми торган җәйге зәңгәр пальтосын киде.* С.Рафиков. *Әллә нигә аркам суыксып тора.* А.Гыйләҗев

**СУЫКСЫНУ** *ф.* Суык дип кабул итү, артык суык дип табу, артык суык дип исәпләү. *Мәдәния, суыксынгандай бөрешә төшеп, ике кулын күкрәгенә кысты.* Г.Бәширов

**Суыксынып тору** Хәзерге моментта яки әледән-әле. *Әллә нигә аркам суыксынып тора.* Казан утлары

**СУЫНДЫРУ** *ф. к.* **суыту**. *Мөмкинме соң ике, пар йөрәкне суындыру?* Ф.Яхин

**Суындыра төшү** Берникадәр суындыру

**Суындырып бетерү** Тәмам, бик нык суындыру

**СУЫНУ** *ф.* 1) Чагыштырмача салкын хәлгә килү, салкынаю. *Нишлисең соң, нәфис чәчәкләрем, Көзләр бит бу. Көннәр суына.* Ф.Дәүләтгәрәева

2) Эсселәгән, кызган хәлдән чыгу; эсселеге кимү, бетү. *Хәзер солы бирергә ярамый әле [атка]. Бераз суынсын; коры печән булганда, бераз бирергә ярый.* Ш.Камал. *Табынга куелган чәй суынган иде инде, күптән суынган иде.* Н.Акмал

3) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә карата кызыксыну бетү, аның белән мавыкмый башлау, аннан бизү, читләшү. *[Зөбәрҗәт] Заһитның җәй башыннан бирле ничектер үзенә карата суынганлыгын тойды.* А.Расих. *Валентин кызны эзләү дәртеннән шушы көнгә кадәр суынмады.* Ш.Бикчурин

4) Хис, дәрт һ.б.ш. бетү, кимү яисә сүрелү. *Синнән туялармыни, йөрәгем минем, канатым, мәхәббәтем суынырлык түгел.* И.Юзеев

5) Тынычлану, ярсудан туктау, психик тотрыклы хәлгә кайту. *Бу авыр кичерешләрдән бераз суынырга, айнырга кирәк иде аңа.* Г.Минский

6) *күч.* Нинди дә булса эш, мәсьәлә һ.б.ш.ның актуальлеге, кызыгы бетү, онытыла башлау. *– Машина күзгедән дә болайрак ялтыраган булыр, үзем дә шул ният белән барыш, – диде шофёр*

*егет, сүзгә суынырга ирек бирмичә...* Ф.Хөсни

**Суына башлау** Суынуга табан бару. *Хатынының баласы булмаганда, бик риза иде мин табып биргәнгә, хәзер үз хатыны бәбәйләгәч, эзе суына башлады.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Суына төшү** Берникадәр суыну; тагын бераз суыну. *Малайларның балык тоту дәрте суына төште.* Ә.Фәйзи. *Чәй суына төшкән иде.* М.Кәбиров

**Суынып бетү** Тәмам, бөтенләй суыну

**Суынып тору** Суыну процессында булу

**СУЫРГЫЧ** *и.* 1) Суыру (II) өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы машинасы, җилгәргеч

2) Суырту I (*2 мәгъ.*) өчен билгеләнгән махсус машина, аппарат, җайланма. *Ак кабаклардай нефть баклары күзгә чагылды. Монда инде табылган нефтьне бакларга җыялар һәм автомат суыргычлар ярдәмендә ерак-еракларга озаталар иде.* А.Расих. *«Йолдыз тузаны»ннан торган менә шул өермә үз күчәре тирәсендә әйләнә һәм бер үк вакытта үзәктәге ниндидер «тузан суыргыч»ка тартылып керә тора.* З.Мифтахов

**СУЫРТКЫЧ** *и.* 1) Суырту (I) җайланмасы, механизмы. *Себерке әйбәтрәкме, тузан суырткычмы?* З.Мифтахов. *Ул вакытта бу кечкенә генә бухтада иренеп кенә эшләүче --- суырткыч машина тавышы белән үзәнлектә җилләр уртасында калган иске тегермән ыңгырашканы гына ишетелә иде.* Казан утлары

2) *иск.* Киптергеч. *Дәфтәр суырткычы*

**СУЫРТУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **суыру** I

2) Насос һ.б.ш. җайланмалар ярдәмендә суыру, суырып алу. *Әнә анда ак калайдан эшләнгән бал суырту машинасы әйләнә. Кузәнәкләрдәге сыек бал, суырту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибәли.* А.Алиш. *[Рәхим] кулына шприц алып, аңа эремә суыртты.* А.Расих. *Хезмәт юлын туган авылы Балтачта үзәк хастаханәнең су суырту станциясе машинисты булып тәмамлый.* Г.Мөхәммәтшин

**Суырта башлау** Суыртырга тотыну

**Суырта бирү** Бернигә карамастан суырту

**Суырта төшү** Бераз суырту; тагын да суырту

**Суыртып бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә суырту

**Суыртып кую** Алдан суырту

**Суыртып тору** Суырту хәлендә булу; әле, хәзер суырту

**Суыртып яту** *сөйл. к.* **суыртып тору**

**СУЫРТУ** II *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **суыру** II

2) Махсус суыргыч механизм, машина ярдәмендә суыру, шуның белән эшкәртү. *Ул тегермәннәрдә игенне, тартып, он иткәннәр, кабыгын суыртып, ярма ясаганнар.* З.Зәйнуллин. *[Колхоз председателе – Мәрьямгә:] Иртәгә кибәк суыртырга эндәшүем.* С.Шәкүров

**Суырта башлау** Суыртырга тотыну

**Суырта бирү** Бернигә карамастан суырту

**Суырта төшү** Берникадәр суырту; тагын да ныграк суырту

**Суыртып бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә суырту

**Суыртып кую** Алдан суырту

**Суыртып тору** Суырту хәлендә булу; әле, хәзер суырту

**Суыртып яту** *сөйл. к.* **суыртып тору**

**СУЫРУ** I *ф.* 1) Сулыш юллары ярдәмендә эчкә һава агымы тарту. *Ул папирос кабызды һәм аны тирән итеп суырды.* А.Шамов. *Бикчәнтәев өстәл өстендәге «Пушка» тартмасыннан бер папирос алып кабызды, тәмләп суырды.* И.Салахов

2) Имү. *[Колын] бик ачыгып туган күрәсең, әнкәсенең сөт тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.* Г.Ибраһимов. *Сөтсез имчәкләрен суыра-суыра Елый аның сабый баласы.* Ә.Ерикәй

3) Бармак һ.б.ш. нәрсәне авызга кабып имгәндәй итү. *Чүкеч тиеп авырттырган бармагын суырып торган Илдар әллә ишетмәде, әллә ишетеп әһәмият бирмәде, әнисенә күтәрелеп карамады.* Г.Гобәй. *Бармак суырган балаларның алдагы тешләре як-якка аерылып үсә икән!* Сөембикә

4) Берәр әйбернең эчендәге нәрсәне һава агымы белән тартып, ияртеп чыгару. *Дәүләтьяров, сөяк суыручы Курманаевка мөрәҗәгать итмичә, гел йорт хуҗасына карап сөйләде.* И.Гази

5) Авызны зур итеп ачмыйча, иренне кыскан килеш кенә аз-азлап авызга алу, эчү. *Кока-кола суыру*

6) Тере организмнан кан, сүл һ.б.ш. сыекчаны үзләренең махсус имгечләре белән эчү (паразит бөҗәкләр тур.). *Каныңны суырырга кунган черкине сытасың.* Т.Миңнуллин. *Ашасын черкиләр колакларыңны, суырсыннар каныңны!* Җ.Юнысов

7) Махсус хортумчыклары аркылы сыеклык эчү (бөҗәкләр һәм кайбер җәнлекләр тур.). *[Бал корты] Еракерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала.* А.Алиш. *Тукранбаш чәчәгендә төклетура тәмләп кенә бал суырып маташа.* Г.Бәширов

8) Авыз эчендә кысып, әвәләп, ялап эретү һәм йоту. *Ул әле күптән түгел генә тартуын ташлаган, ләкин янындагы кешеләр тартканда күңеле кытыклана, шуңа конфет суыра иде.* С.Рафиков. *Әхмәди, шикәрне суырып балалар сыман иреннәрен ялмагач, телен чартлатып куйды.* Г.Бәширов

9) Һава агымы ярдәмендә нинди дә булса сыеклыкны берәр җирдән агызып, кудырып чыгару (насос һ.б.ш. тур.). *Дон-Кихот көне-төне селкенеп, нефть суырып утыручы көянтәгә охшаган нәрсәгә асылынып, берничә мәртәбә егылып та төште.* Р.Вәлиев. *Тавышсыз-тынсыз гына җир астыннан нефть суыручы ап-ак фонтан арматуралары [күренде].* А.Әхмәт

10) Туфрактан, судан туклыклы матдәләр алу (үсемлекләр тур.). *Үсемлек үзенең тамырлары аша җирдән суырып ала [азыкны].* А.Расих. *Яфрак коелу – көз һәм кыш көннәрендә үсемлекләрдә суның парга әйләнүе кимүгә җайланыш ул. Кышын үсемлек тамырлары туфрактан салкын суны суыра алмый.* Биология

11) Эченә тартып кертү, батыру, йоту (сазлык, упкын һ.б.ш. тур.). *Муенга юеш кар ява, аяктагы галошны пычрак суыра, ә урамда йөрмичә ярамый.* М.Мәһдиев. *Аның артыннан ук*

*сазлык тагын берничә кешене суырды.* Н.Вахитов

12) Һава агымы ярдәмендә төтенне яхшы үткәрү; тарту (моржа һ.б.ш. тур.). *Ул улы белән бергәләп мичнең бер өлешен сүтте, төтен юлларын көлдән, корымнан арчыды, аларның ныклыгын, суыру көчен тикшерде.* А.Шамов

13) Кагып, кидереп, тыгып куелган нәрсәне урыныннан тартып, йолкып алу, чыгару. *Суырып алган кадаклар урынында ямьсез булып тирән эзләр уелып калган.* Риваять. *Кайсыдыр утынга дип читәнне суырырга тотынды.* И.Гази. *Робот чыгып киткәч, Тимерхан тышына батынкы хәрефләр белән «Роботлар Казаны» дип язылган капсуланың бөкесен суырып чыгарды.* З.Мәхмүди

14) Үсемлекне яки тамырлы әгъзаны үсеп утырган, урнашкан җиреннән йолкып чыгару. *Черек тешне суырып алып кына котылалар.* В.Имамов. *Эш бетте, язны гына көтәргә калды дигәндә, кеше ышанмаслык хәлләр: башлап, ике кечкенә чыршыны, тамыры белән суырып, җиргә ыргытканнар.* Ф.Гыйбатдинов

15) *күч.* Таушалдыру, ябыктыру, зәгыйфьләндерү (борчу, кайгы һ.б.ш. тур.). *Бу тормыш аны башка шәкертләр кебек үк суырган; тумыштан таза, киң күкрәкле һәм гайрәтле бала саргаеп кипкән егет хәленә әйләнергә якын иде.* Г.Ибраһимов

16) *күч.* Көчләү, алдау, мәҗбүр итү һ.б.ш. юл белән кемнән яки каян да булса берәр нәрсә алып тору, аны табыш чыганагы итеп файдалану. *Баязит әйтә иде, өйрәнмәгәнрәк токынкарның серләрен алыр өчен, күрше камерага охранка агентын утырталар да, стена аркылы шулай сөйләтеп, материал суыралар, ди торган иде.* Г.Ибраһимов. *Бүгенге заман феодаллары да уңайлы урынга утырып, үзләре уйлап тапкан тариф буенча акча суыру һөнәрен матур гына үзләштереп киләләр.* Безнең гәҗит

17) *күч.* Көч-куәтне, чыгымны бик күп алу. *[Мәхәббәт борчулары] үзәкне өзәләр, күңелсезләндерәләр, көчне суыралар.* Г.Әпсәләмов. *Төзелеш бит, шул суырды инде аны [акчаны].* Казан утлары

**Суыра башлау** Суырырга керешү. *Фашистлар аны шулай таң атканчы азаплаганнар. Тырнакларын суыра башлаганнар ---.* Г.Бәширов. *[Гәрәй] Кулындагы сөякне ялый, суыра башлады.* Г.Гыйльманов

**Суырып бетерү** Тәмам, тулысынча суыру. *Яфраклары соңгы суын суырып бетергәч, без аны [агачны] кисәчәкбез.* З.Мәхмүди

**Суырып карау** Сынау максаты белән суыру. *Шәйхи карт та сигараны бер суырып карады һәм, ютәлено буылып: – Бу – ярманнарның үз тәмәкесе түгел, аларның үзләрендә үсми ул, төрекләрдән алган тәмәке бу, – дип, кешеләрне ышандырды.* М.Мәһдиев

**Суырып кую** Бер тапкыр суыру. *– Әй-й тәмле дә балык иде, – дип, Фаягөл телен суырып куйды.* А.Хәсәнов

**Суырып тору** Даими, өзлексез суыру; суыру процессында булу. *[Зариф:] Мәскәүгә барып әйбәтләп урнашырбыз. Акчалата без аңардан [бай инженердан] суырып торырбыз.* Ш.Камал

**Суырып яту** *сөйл. к.* **суырып тору**. *Чәчәктән чәчәккә очканда, мәк чәчәгендә бал суырып ятканда, калын тавыш белән тагын кемдер эндәшә: – Бал корты, бал корты! – ди.* А.Алиш

**СУЫРУ** II *ф.* Ашлыкны һ.б.ш. җил яки суыргыч ярдәмендә кибәктән, чүп-чардан аралау, чистарту; җилгәрү. *Көндезге аш вакытында Сафа, суыру машинасының иләкләрен рәтләргә дип, ындырда берүзе калды.* А.Шамов. *Көндез суккан ашлыкларны кичен бергә җыеп көшелгә өябез. Әти шуларны җил уңаена торып, көрәк белән суыра.* З.Бәшири

**Суыра башлау** Суырырга тотыну

**Суыра бирү** Бернигә карамый суыруны дәвам итү

**Суырып алу** Аз гына яки тиз генә суыру

**Суырып бетерү** Суыруны тәмамлау

**Суырып тору** Хәзерге моментта суыру

**СУЫРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **суыру** I

2) *күч.* Берникадәр ябыгу; кечерәеп, нечкәреп калу. *Синең ялганыңны сизгәннән соң, мин ябыктым, суырылдым.* Г.Кутуй. *Профессор алдында инде үз киемен кигән, йөзе шактый суырылган, саргайган, ләкин сәламәтләнү сөенеченнән яктырган Асия басып тора.* Г.Әпсәләмов

**Суырыла башлау** Суырылырга тотыну. *Үзенең төпсез сазлыкка суырыла башлаганын сизсә дә, Хамисә бу оҗмахтан ваз кичәргә теләмәде.* Ә.Дусайлы

**Суырылып бару** Һаман суырылу. *Рөстәм, суырылып барган йөрәгенең әрнүләрен җиңеләйтергә теләгәндәй, автобус артыннан атлады, аның белән бергә адымнарын тизләтә барды һәм йөгерүгә күчте.* М.Кәбиров

**Суырылып бетү** Тәмам суырылу. *Эчендәге кешене кеше итә торган нәрсәләр суырылып бетеп, күңелең тәмам бушагач, яшәүнең дә кызыгы калмый икән аның.* Ф.Садриев

**СУЫТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса суыту өчен хезмәт итә торган махсус җайланма, аппарат. *Кабиналарда температура күтәрелгәннән-күтәрелде. Тирләп-янып пешкән сәяхәтчеләр барлык суыткычларны эшкә җиктеләр, ләкин бу да артык ярдәм итмәде.* А.Тимергалин. *Урта бер җирдә гаять зур урынны биләп, акка буялган цистерна-термос тора. Аның як-ягында сөт суыткычлар.* М.Хәсәнов

2) Азык әйберләрен суыту, туңдыру, бозмыйча саклау өчен хезмәт итә, түбән температура саклый торган махсус җайланма, шкаф, бүлмә һ.б.ш. *[Яңа бүлек мөдире] Прилавка артындагы суыткычларны арткы ишек янына күчертте.* Л.-Х.Таналин. *[Хатын] Үзенең өйдән чыгу вакытын иртәрәк күрсәтеп, Сергейга суыткычтан аш алып ашарга кушылган язу калдырырга да онытмады.* М.Кәбиров

**2.** *с. мәгъ.* Суыту өчен хезмәт итә торган. *Цехларның һәр почмагында, һәр җирендә хезмәт кайный. Түшәмгә асылмалы краннар беркетәләр, станоктан станокка суыткыч сыекча бирү өчен, металл торбалар уздыралар.* А.Расих. *Өйнең бер бүлмәсендә электрон плитә белән суыткыч җайланма, икенче бүлмәсендә ванна бар иде.* Н.Фәттах. *Кызкай аңар кирәкле товарны суыткыч шкафтан идән уртасындагы үлчәгечкә ташый.* Л.-Х.Таналин

**СУЫТУ** *ф.* 1) Суыграк хәлгә китерү, суык итү, җылылыгын яки кайнарлыгын бетерү яисә киметү. *Садыйк, бал калагы белән чәйне суыта-суыта, үзенең тартып чыгарган кәгазьләреннән берсен укырга тотынды.* Г.Ибраһимов

2) Кызганлыкны, эсселәгәнлекне басу, бетерү. *Атларны тугарып, суытырга бәйләп куйдык.* М.Гафури

3) *з.-сыз* Көннең суынуы, салкынаюы турында. *Көннәр суытып, ашарга әйбер таба алмый башлагач, Дөя үзен суйдырырга риза була.* Әкият. *Көннәр суытуга һәм язга кадәр кеше өйләрендә укулар дәвам итә.* И.Нуруллин

4) Мәхәббәт, дәрт, ярсу һ.б.ш.ны бетерү, киметү яки сүрелдерү. *Хәлимнең фронтка китү дәртен сүзләр белән генә суыта алмагач, үз янынан җибәрмәү чарасына керешә [әтисе].* Г.Гобәй. *Аның сабыр, тыныч карашы Гәрәйне дә бераз суытты.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Урлау

**Суыта бару** Акрынлап суыту. *Битләрне салкын чеметә, югарырак күтәрелгән саен суыта бара ---.* Сөембикә

**Суыта башлау** Суытырга тотыну

**Суыта төшү** Берникадәр суыту; тагын бераз суыту. *Тышта тагын да суыта төшкән бугай.* К.Нәҗми. *Кич булу белән һава суыта төшкән. Күк йөзе ачылган, йолдызлар калыкканнар.* Ә.Еники

**Суытып бетерү** Тәмам, бик нык суыту

**Суытып җибәрү** Кинәт суыту; бераз суыту. *Кичкә бераз суытып җибәрде.* Ф.Яхин. *Өч көн өзлексез яңгыр яуды-яуды да, кинәт суытып җибәрде.* Д.Аппакова

**Суытып кую** Кинәт суыту; алдан ук суыту. *Шулай да кичкә таба кинәт кенә суытып та куйды.* Ф.Яхин

**Суытып тору** Әле, хәзер суыту

**СУЮ** *ф.* 1) Кемне, нәрсәне дә булса бугазын кисеп, канын агызып үтерү. *Төн уртасына кадәр мал сую урыны турында сөйләшеп утырдылар.* Р.Вәлиев. *Фәргать абыйның кайтуына тавык суясы, мунча ягасы бар.* В.Гали

2) Нинди дә булса үткен корал белән чәнчеп, кадап үтерү. *Фашистлар --- басып кереп, кешеләребезне суя, шәһәрләребезне, авылларыбызны яндыра башлады.* Г.Бәширов

3) Тәнне кан чыгарлык итеп ышкытып кырдыру, җәрәхәтләү, чиләндерү. *Таякның сындырылган кытыршы башы уч төбен суйды. Чип-чи кан.* М.Хәсәнов

4) Тирене уеп, аерып җәрәхәтләү; тунау. *Дошман солдатлары ак каенга Чибәр кызны бәйләп куйдылар. Каен тузы кебек тиресен суеп, Күкрәгенә йолдыз уйдылар.* Ә.Ерикәй

5) Агач кабыгын каезлап, кәүсәсеннән аеру, куптару. *Эшләп ашагыз, дигән сүзне ишетергә туры килгәнгә, энемне ияртеп, тал кабыгы суярга йөри башладым.* М.Гафури

6) *күч.* Үтә җаваплы, хәлиткеч берәр вакытта тоткарлык ясап, кирәкмәгән эш эшләп һ.б.ш.лар белән кемне дә булса бик уңайсыз хәлгә кую. *Суйды бит ул юньсез үзенең урынсыз соравы белән.* Ә.Еники. *Эх-х, әтисенең шул кирәбеткәнлеге вакыты белән суя ла!* М.Хәсәнов. *– Бездә бар көчеңне салып намус белән башкарган хезмәтне бәяләү юк, – дип сөйли. – Шул хәл суя.* Х.Камалов

7) *күч.* Бик каты җәфалау, газаплау. *[Солдат:] Бу «Отче наш»лары белән суялар бит, Сәфәр малай.* Ф.Хөсни

◊ **Суеп каплагандай** *к.* **суеп каплаган**. *Кызлары да суеп каплагандай әниләренә охшаганнар: әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр...* Ә.Еники. **Суеп каплаган** 1) Бик нык охшаган, нәкъ үзе. *Командирга суеп каплаган бит, Охшап тора бөтен җире дә.* Н.Нәҗми. *Туры, бераз гына югары чөелгән танаулы, түгәрәк йөзле ир – килеш-килбәте белән суеп каплаган актёр Кирилл Лавров.* А.Хәлим; 2) Бик туры килә, җавап бирә, яраша торган. **Суйган да каплаган** *к.* **суеп каплаган**. *Аның исеме Агзаметдин, ләкин аны үз артында бөтен авыл халкы Аждаһетдин дип атый. Исеме гаҗәп туры килгән. Суйган да каплаган! Каян тапканнар!* А.Шамов

**Суеп ату** Тиз генә яки җиңел генә сую. *Ниндидер хатын-кызлар сугышларда чыныккан дистәләгән ир-атларны суеп ата.* Р.Сәгъди

**Суеп бетерү** Тәмам, бик нык сую; барысын да сую. *Берзаман кайтсам, посёлок тын: көтү юк, сөт исе дә аңкымый, сыер мөгрәве дә ишетелми. Суеп бетергәннәр мәхлукларны!* Ә.Еники. *Итекләр үкчәне суеп бетерделәр.* Р.Батулла

**Суеп калу** Суярга өлгерү, вакытлы сую. *Куркып җан биргәнче суеп калырга кирәк [куянны], диде ул.* Р.Батулла

**Суеп кую** Алдан ук сую хәстәрен күрү, суеп әзер итү; ялгышлык белән яки көтмәгәндә сую. *Чыннан да, без алтын йомырка сала торган тавыкларны суеп куймыйк.* Т.Гыйззәт. *Районнан килгән начальникларны ашатырга колхоз һәрвакыт сарык суеп куя, шуңа амбарда ит бетеп тормый.* В.Нуруллин

**Суеп ташлау** *сөйл.* Тиз генә яки ачу белән сую. *Исерек карт, кан баскан күзләрен бернәрсә дә аңламыйча миңа текәп торды да, карлыккан, тонык тавыш белән әйтеп салды: – Якты дөньядан туйдыңмы әллә? Хәз-зер суеп ташлыйм үзеңне!* З.Зәйнуллин. *Ул сине иң якын туганын очраткандай кочаклап алырга да, ягымлы гына елмаеп суеп ташларга да мөмкин.* И.Сираҗи

**Суеп тору** Әле, хәзер сую; сую эше белән шөгыльләнү. *Шәмәрдән кош комбинатында тавык суеп тора.* М.Мәһдиев. *--- кеше гел мал суеп тормый бит. Шуңа апрельгә заказлар шактый кими.* Л.Йосыпова

**Суеп чыгу** Рәттән, барысын да, баштан ахыргача сую. *Хәленнән килсә, барлык каршы дәшүчеләрне дә суеп чыгар иде ул.* Р.Сәгъди

**Суеп яту** *к. сөйл.* **суеп тору**. *Моннан биш-алты көн элек, абзарыбызда сыерыбызны суеп ятканда, әсләренә барып кергән.* Т.Гыйззәт

**Суя башлау** Суярга тотыну. *Я, менә иртәгә большевиклар килеп, барыбызны берәм-берәм суя башласалар?* К.Тинчурин. *Татарстанда да авыл халкы, фермерлар малларны суя башлаган.* Б.Тимерова

**Суя төшү** Бераз сую. *Аяк киеме табан тиресен суя төшкән*

**Суя язу** Чак суймый калу. *Төрмәдә чакта да камерадашын суя язган Тутыкны карцерга утырту Морат өлешенә туры килде.* Н.Әхмәдиев

**СҮГЕНҮ** *ф.* Сөйләгән чакта әдәпсез, әшәке, оятсыз сүзләр, гыйбарәләр куллану. *Шунда гына мин, әтиемнең сабыры төкәнгәч, җирләр-күкләр яңгыраганны үз колагым белән ишеттем: ул минем алда яман каты итеп беренче мәртәбә сүгенде.* К.Миңлебаев. *Раил берөзлексез сүгенде, тәмәке тартты.* Р.Кәрами

**Сүгенә башлау** Сүгенергә тотыну. *– Болай ярамый бу! Ире кайда, горбун тәре! Нәрсә бу? Нигә кирәк!.. – дип сүгенә башлады [Насрый].* Ш.Камал. *Кемдер ачы итеп кычкырып җибәрде, кемдер сүгенә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Сүгенә бирү** Бернәрсәгә карамастан сүгенү. *Гыйльман: – Ни кирәген күрерсең, карт эт! – дип сүгенә биреп, ишеккә кул салырга өлгермәде, аннан --- сирәк ак чәчле баш күренде ---.* Г.Ибраһимов. *Алар [надзирательләр], нигәдер, мәхбүсләрнең сүгенүләренә игътибар итмиләр генә түгел, кул селтиләр иде. Сүгенә бирсеннәр, янәсе.* И.Салахов

**Сүгенә язу** Чак кына сүгенмичә калу

**Сүгенеп алу** Берара, кыска вакыт яки бер тапкыр сүгенү. *Шул мәлдә ачы итеп, яман сүгенеп алды.* В.Нуриев. *– Фу сезне, ясалып бетмәгән күзле бүкәннәр, – дип сүгенеп алды ул.* Х.Мәрдәншин

**Сүгенеп җибәрү** Көтелмәгәндә сүгенү. *Равил кинәт кенә әшәке сүзләр белән сүгенеп җибәрде дә: «Менә мин сезгә күрсәтәм хәзер!» – дип, буа ягына йөгерде.* В.Нуруллин. *– Нәрсә син миңа маңка башың белән характер күрсәтеп торган буласың, анаңның ләхет тактасын!.. – дип, бик әшәке сүгенеп җибәрде.* Ш.Алпар

**Сүгенеп йөрү** Даими, һәрвакыт сүгенү. *Карт тагы зәһәрләнеп дөньяга, Аллага, байга үч итеп, сүгенеп йөри торган булды.* Г.Ибраһимов. *Менә хәзер, Шәкүр киткәч, инде тәмам айнып җиткәч, үз-үзен тиргәп, сүгенеп йөри Афанасий атакай.* Н.Акмал

**Сүгенеп кую** Кинәт бер мәртәбә сүгенү. *Карый шундук урагын җиргә атып бәреп турайды да әшәке итеп сүгенеп куйды.* М.Галәү. *Сакалбай дигән тимерче күкрәк хәтле сакалы буйлап аккан канын киндер алъяпкычына сөртеп алды да аты-башы белән сүгенеп куйды.* М.Хәбибуллин

**Сүгенеп ташлау** Кызулык, ялгышлык белән, көтмәгәндә сүгенү. *Элегрәк ни карагандыр бу хатын. Даниал чак кына сүгенеп ташламады.* Р.Кәрами

**Сүгенеп тору** Хәзер, шушы моментта сүгенү. *Гармунчы исә, гармун калдыкларын кочагына җыеп тоткан килеш, мулланы каргый-каргый сүгенеп тора иде.* М.Галәү. *Гәҗитә укыйсы килми, гайбәт-яңалыклар тыңлыйсы килми – эчтән генә сүгенеп торабыз чиратта.* Р.Батулла

**Сүгенеп яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта сүгенү. *Насрый шулай сүгенеп ятканда, казармадан килеп чакырдылар.* Ш.Камал. *Һаман аты-юлы белән сүгенеп ята икән.* Р.Батулла

**СҮГЕНҮЛЕ** *с.* Сүгенү сүзләреннән торган. *Шуңа матросларның сүгенүле сукрануларына әллә ни әһәмият бирмичә, фанер чемоданнарын янәшә куеп, озата килүчеләргә кул болгарга керештеләр.* Казан утлары. *Менә без дә килеп җиттек: музыкаль киоскларда хәзер, тозсыз, мәгънәсез, буш җырларга өстәп, бик тә «мәгънәлеләре» дә сатыла башлады – саф татарча сүгенүле җырлар.* Татарстан яшьләре

**СҮГЕНҮЧӘН** *с.* Сүгенү гадәте булган; сүгенергә ярата торган. *Ә улыма: «Аларның әниләре, сүгенүчән кешене Ходай яратмый, дип әйтергә онытканнар», – дидем.* Ирек мәйданы

**СҮГЕШ** *и.* 1) Сүгү яки сүгенү эше, процессы. *Сүздән сүз чыгып, [эш килешүчеләр арасында] сүгеш китте.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Инде тормыш үз агымына салындымы, үзара кычкырыш, --- сүгеш китә.* Р.Рахман

2) Сүгү, сүгенү сүзләре. *Әллә никадәр сүгешләр, каргышлар, куылулар...* Ф.Әмирхан. *Күтәрдем зур сабыр берлән сүгешләрне, каһәрләрне!* Н.Исәнбәт. *Сүгеш белән һава тулган.* К.Нәҗми

**СҮГЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **сүгү**. *Һәр мәсьәләдә чалмалылар әллә нишә төркемгә бүленеп кычкырыштылар, сүгештеләр, хурлаштылар, көфер пичәте басыштылар.* М.Галәү

**Сүгешә башлау** Сүгешергә тотыну. *Ике кеше ачуланыша һәм сүгешә башласалар, шуның гөнаһы сүгешүне башлаучыга була.* Р.Фәхретдин

**Сүгешеп китү** Кинәттән яки көтмәстән сүгешә башлау, нинди дер сәбәп белән сүгешергә тотыну. *Шуннан Николай белән чынлап торып сүгешеп тә китә иделәр.* Ш.Камал

**СҮГҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса әрләү, орышу, ачулану, канәгатьсезлек белдерү. *Бүлмәсенә кайтып кергәндә, ул Вәлүкне сүкте: «Я имде, эт нәрсә, кич ялга каршы очраган булса...».* А.Алиш. *Үзем планерда төшкән теге егетләрне сүккән булам, үзем эчтән сөенәм.* М.Галиев

2) Кемне дә булса гаеп итеп, тупас формада, әшәке сүзләр кулланып орышу; берәүгә карата әшәке сүзләр куллану. *Операция вакытында иптәшем авыртуга түзә алмый, үзен үзе белми кычкыра, докторны теленә ни эләксә шуның белән сүгә башлады.* Һ.Такташ

**Сүгә башлау** Сүгәргә тотыну. *Килде дә, турыдан-туры тупас рәвештә, әти-әниләре алдында Мөбинәне сүгә башлады ---.* М.Җәлил. *Сез нинди хәлдә калыр идегез икән бу вакыт, анысын белмим, тик безнең мәҗлес бу хәбәрдән соң шау-шулы җыелышка әйләнеп китте: һәрбер кунак, үз чиратында, брак ясаучыларны сүгә башлады.* А.Расих

**Сүгә бирү** Һаман, бертуктамыйча, бернәрсәгә карамастан сүгүне дәвам итү. *Ана кызын сүгә бирде*

**Сүгә тору** Әледән-әле сүгү; әлегә сүгү. *Эстраданың бу кимчелеген сүгә торабыз, ә аңа карап кына мәгънәсез, өч ноталы җырлар кимеми, арта гына бара кебек.* Сәхнә

**Сүгеп алу** Аз вакыт эчендә, бераз гына сүгү. *Күрше карчыгын да сүгеп алды, аны күрше авылга туганнарына илткән иде.* Н.Акмал. *Кунаклар башта, гадәт буенча, хөкүмәтне сүгеп алдылар.* И.Хәйруллин. *– Вәйт, идриткүдрит, фатирыма чүп-чар төяп кайтам икән ләбаса! – ди-ди үз-үзен сүгеп алгач, сүзен дәвам итте.* Шәһри Казан

**Сүгеп ату** *к.* **сүгеп ташлау**. *Гел юктан гаеп табып, мастерларны сүгеп атты ---.* Р.Кәрами. *--- балалар бакчасы мөдире балаларга акыра-кычкыра, сүз әйтсәләр, ата-аналарны да сүгеп*

*ата: «Мин нишләгәнемне беләм, мин психолог», – дип кенә җибәрә.* Мәдәни җомга. *Илһамия ханымның тавышыннан сиздем: мине тотып сүгеп атмый түзеп кенә торды.* Безнең гәҗит

**Сүгеп йөрү** Кабат-кабат сүгү, озак вакыт сүгү. *Ошатканнары канәгать елмаеп куя да берни дәшми, ә ошатмаганнарының бер өлеше мине сүгеп йөри ---.* М.Кәбиров. *Театр директоры, бирергә кушкач та бирәсе килми генә биреп: «Таратып бетерә театрны», – дип, директорны сүгеп йөри икән.* Сәхнә

**Сүгеп карау** Сынар өчен сүгү. *Аңар менә, мәктәпкә килгәч, мулла начар дип сүгеп карасыннар, яхшы кеше, диячәк.* Татарстан яшьләре

**Сүгеп ташлау** Ачу белән, кызып китеп, бик каты сүгү. *Туры өйгә кайтып кирәсе урынга егетләр янына кереп онытылуына ачуым кузгалып, үпкәле сүз әйтсәм, тагын тузына: «Сине дусларыма алыштыраммы соң?!» – дип, шунда ук яман сүгеп ташлый торган булды.* Ш.Алпар. *– Ну түтәй, даёшь син! – дип сүгеп ташладым тегене.* Д.Булатова

**Сүгеп тору** Һәрвакыт, әледән-әле сүгү; әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда сүгү. *Син имтихан тапшырган вакытта, берәр якын кешең сине бик начар сүзләр әйтеп сүгеп торырга --- тиеш.* Ватаным Татарстан

**СҮЗ** *и.* 1) *лингв.* Предмет, күренеш, вакыйга, эш-хәлләр һ.б.ш.ларны белдерә торган, бер яки берничә аваздан торган иң кечкенә лексик берәмлек. *Ачуы килгән чакта шулай бер телдә дә булмаган ясалма сүз әйтеп бушана торган гадәте бар иде аның.* М.Галиев. *Морфология грамматиканың бер өлешен тәшкил итә, аның төп өйрәнү объекты – сүзнең мәгънәле кисәкләре: морфемалар, сүзләр һәм сүзформалар ---.* Татар теле морфологиясе

2) *лингв.* Сөйләмдә логик яки грамматик мөнәсәбәтләрне белдерә торган, мөстәкыйль фонетик үзлеккә ия лексик берәмлек. --- *Г.Ибраһимов татар телендә килешне гомумән танымый, килеш кушымчаларын аерым ярдәмлек сүз төркеме – кушымта итеп карый.* Фән һәм тел

3) Гыйбарә, әйтем. *Борынгылар әйткән сүз*

4) *купл. форм.* Музыкаль яки шигъри әсәр тексты. *Гимнның сүзләре аның музыкасы характерына, темпы һәм үлчәменә дә туры килүе шарт.* Р.Нуруллин. *Биредә, янында гына очы-кырые күренгесез диңгез тирбәлгәндә, күккә олгашкан мәһабәт наратлар күләгәсендә җырның сүзләре башкачарак яңгырый.* Д.Булатова

5) Әңгәмә, сөйләшү; сөйләп бирелә торган фикер. *Унөч яшьтә генә булуына карамастан, ул бик тере, зирәк акыллы һәм сүзгә оста малай булып, аның бу сыйфатлары әнисе Җиһан абыстайдан күчкән иде.* М.Галәү. *– Туктагыз әле, егетләр, – дип сүзгә кушылдым.* Ф.Яруллин

6) Нинди дә булса җәмәгать алдында телдән ясала торган чыгыш. *– Ватандашыбыз Мөрхәй мирзаның хатынына кул салганы вә --- аны мәсхәрә итәргә уйлаганы өчен, бу бәндәне үлем җәзасына тартырга! – дип карар чыгардылар да Алып Бәргәнгә соңгы сүз бирделәр.* Р.Батулла. *Ә минем юбилей кичәсендә әнкәйгә, әлбәттә инде, сүз бирделәр.* Р.Миңнуллин

7) *юр.* Үз фикереңне белдерү хокукы. *Мондый «интеллигент» Татарстан суверенитетын да, сүз иреген дә, халык азатлыгын да үз мәнфәгате өчен һич икеләнмичә сатып җибәрә!..* В.Юныс. *Сүз ирегe бер нәрсә, әмма чамалап сөйләшмәсәң, аның нәтиҗәләре үзен бик тиз сиздерә башлый.* Р.Вәлиев

8) Караш, фикер; бәяләмә. *Җиңгинең сүзе хак булса, тагын берәр айсыз кайтмаячаклар, ди.* В.Нуруллин. *Сабир һаман да үз сүзендә калды ---.* Ф.Яхин

9) Киңәш, нәсыйхәт, үгет. *Ил сүзен тоткан – ир булыр ---.* Дастан. *Син өлкәннәр сүзен тыңла.* М.Маликова. *Атасы никадәр генә кырыс булса да, атасын яратып хөрмәт итсә дә, Кәбир ата сүзен тотмас дәрәҗәдә үзбаш фикердә иде.* Р.Батулла

10) Гайбәт, шелтә, тәнкыйть, имешмимеш. *Әллә бер-бер сүз ишеттеңме?* Г.Исхакый. *– Кешегә сүз ирештермәсен, ялган сөйләмәсен, итагатьле булсын, – диде.* М.Юныс. *Җитди хаталар җибәрде, шуның аркасында шелтә алды, күп сүз ишетте.* З.Мурсиев

11) Вәгъдә; ант. --- *заманында Фәләхнең әтисе Розаның әнисе Рәйханә ханым белән сөешеп йөргән, хәтта өйләнешергә дә сүз куешкан булганнар.* В.Нуруллин. *– Бер дигән биюче ясыйм мин үзеңнән, – дип, сүзеннән кайтмады хатыны.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Сүз алышу** Кара-каршы сөйләшеп алу, кыска гына әңгәмә кору. *Пассажда бер яшь хатын янына туры барып, аның белән саулык-сәламәтлек сорашырлык кадәр генә сүз алышты ---.* З.Бигиев. *Алар тагын бер-ике сүз алыштылар, тик сүзсез торган чакларында ныграк аңлаштылар бугай, туктаусыз елмайдылар.* А.Гыйләҗев. *Я су буенда, я абзарда, я йоклаганда ике-өч сүз алышабыз да шуның белән бетте.* Р.Рахман. **Сүз ара сүз чыгу** *к.* **сүз иярә сүз чыгу**. *Сүз ара сүз чыгып, мин --- профилактика турында сөйләп алдым.* Г.Кутуй. *Ничектер сүз ара сүз чыгып сөйләшкәндә, марҗа белән яшәгән бер азәрбайҗан кешесе миңа болай диде ---.* З.Зәйнуллин. *– Бөтенләй башка – яңа тормыш башланды, әни, синең өчен, – дим үзенә, сүз ара сүз чыгып.* Р.Мөхәммәдиев. **Сүз арасында** 1) Бүтән сүзләр белән бергә, шулар рәтеннән, төп сүзләргә кушып. *Укый-укый, сүз арасында кайбер китап сүзләре дә кыстырып җибәргәләү дәрәҗәсенә ирешә [Гәрәй].* М.Әмир; 2) Башка нәрсә турында әйтелгән фикергә кушып, бер уңайдан. *Без төрлесеннән азмаз сөйләшеп алдык. Сүз арасында кемнең кайда эшләве, ничек эшләве, ничек көн үткәрүе дә беленде.* К.Басыйров; 3) Сөйләшкән арада, сүз сөйләү белән бергә. *Сүз арасында самавыр тагын яңартылды.* К.Нәҗми. **Сүз артыннан сүз чыгу** *к.* **сүз иярә сүз чыгу**. *Ярар, Газинур улым. Сүз артыннан сүз чыга. Әзрәк черем итеп алырга да кирәк.* Г.Әпсәләмов. **Сүз белән сыйлау** *ирон.* 1) Кунакны аш-су белән сыйлыйсы урынга, сүз белән мавыктыру. *Сүз белән сыйлап чыгарды.* Р.Вәлиев. *Әйдә, юлдан килгән кешене сүз белән сыйлап утырам, чәй эчик, әле яңа гына кайнап чыккан иде, мактап йөрисең икән!*

Безнең гәҗит; 2) Тормышка ашмастай, буш, ялган вәгъдәләр бирү; эшне сүз белән алмаштыру. *[Солдатлар – Вакытлы хөкүмәт агитаторына:] Ә кайчан өйгә кайтабыз? --- Безне сүз белән күп сыйладыгыз, эшегезне күрмибез.* Ф.Хөсни. *Акыллы эшләп күрсәтсен, Сүз белән сыйламасын. Үзе булдыра алмаса, Бездән эш сорамасын.* Ф.Дәүләтбаев. **Сүз бер булу** 1) Әйткән сүзеннән кайтмау, сүзеңдә тору, сүзен үтәү. *Ирләр сүзе бер булыр.* Мәкаль. *Хәер, Биби әби, минем сүзем бер булыр, --- кирәкми, юк, миңа зыяндашлы, янә череп сасып беткән төче зәхмәтле кыз.* Ф.Халиди. *Син вәгъдә бирдең. Егет сүзе бер була, шулаймы?* В.Нуруллин; 2) Алдан килешеп кую, бер фикердә булу. *Җир эшләрендәге спецлар белән Вәли Хәсәновның сүзе бер. Болар, һәммәсе берләшеп, алпавыт Алексейның байлыгын арттырмак булалар.* Г.Ибраһимов. **Сүз берегү** Бердәмлеккә ирешү, аңлашу, бер фикергә килү. *Булса да сүзләр береккән, Бу өчәү [Арыслан, Юлбарыс һәм Мәче] аерым яши.* Г.Тукай. **Сүз беркетү** Бердәм эш итү турында сөйләшеп кую, килешү; алдан килешеп вәгъдәләшү. *Сөйләшеп сүз беркетәләр дә Таңбатыр яткан шалашның ишегенә аркылыга кылыч куялар ---.* Әкият. *Сафа белән Саҗидәнең сүз беркеткән кебек икесе бер көнне килүләре Җиһанга сәер тоелды.* М.Галәү. *--- хәзрәтләр, үзләре исән чакта, балаларын --- кавыштырып калырга сүз беркетә ---.* Р.Әмирхан. **Сүз берләшү** *к.* **сүз беркетү**. *Бабайлар әйтерсең лә сүз берләшкәннәр: алар күңелләре белән, --- төпле акыллары белән мондый эшнең ахыры барыбер хәерле булып чыкмасын тойганнар, белгәннәр.* А.Әхмәдуллин. *Тагын берәр атнадан соң «Огонёк»ка киноga килсәк, сүз берләшкән кебек, яңадан шул ук егетләр каршыбызда пәйда булдылар.* Ш.Алпар. **Сүз бирү** 1) Вәгъдә итү, ышандыру. *Икенче хатта мин сиңа үземнең үткән мәхәббәтем турында сөйләргә сүз биргән идем.* М.Җәлил. *--- мин бит ул вакытта Мәрьямгә, минем өстемә йөкләгән бурычны үтәрмен, дип сүз бирдем.* И.Хуҗин. *Үткәр сөйләшкән фикерләрне, башкар сүз биргән эшләрне.* Р.Вәлиев; 2) Ант итү. *Үлгәндә дә хәтта бу җирдән Чигенмәскә алар сүз биргән.* Ә.Исхак. *Мин күргәннәремне Шәмгунга сөйләмәскә сүз бирдем.* Ф.Шәфигуллин. *Ык-мык итеп булса да, Нәсимәләрнең серен ачмаска сүз бирдем.* Г.Гыйльманов. **Сүз бистәсе** Сүзчән, сөйләргә яратучы кеше. *Әй мин, сүз бистәсе, самавыр турында бөтенләй онытканмын.* И.Гази. **Сүз булсын дип** Нәрсә дияргә белмәгәннән, аптыраганнан гына әйтелгән сүзләр. *Минем саргайганым юк. Суксам иңнәрен сындырырлык тазалыгым бар, моны тик сүз булсын дип лыгырдыйлар инде.* Г.Ибраһимов. *Әнисенең, бу чәчләреңне кистерсәң, Ходай тотар, дип куркытып килүе сүз булсын дип әйтү генә булгандыр.* Ак калфак. **Сүз буткасы** *шелт.* 1) Эш эшлисе урынга сөйләнә торган файдасыз, буш сүзләр. *Сәйдәшев исә сүз буткасын дәвам иттерде: – Җиһаншин абыеңның машинасы нинди?* М.Насыйбуллин. *Гөлкәйне бу сүз буткасы туйдыра башлаган иде.* Х.Ширмән. *– Әйе, абзаң бик күпне күргән һәм кичергән шул! – диеп уйлап, егет үзенең артык күп акыллы сүзләр әйтеп ташлаганын һәм бу сүз буткасын күптән туктатырга кирәклеген аңлый башлаган иде.* З.Мурсиев; 2) Бәйләнешсез сүзләрдән торган, мәгънәсе ачык булмаган сөйләм. *[Начар җавап бирүче укучыдан] мәгънәсез сүз буткасы ишетеп, бөтен класс көлә башлады.* А.Тимергалин. **Сүз буткасы кайнату** *к.* **сүз буткасы пешерү**. **Сүз буткасы куерту** *к.* **сүз буткасы пешерү**. *Сүз буткасы куертып, синең белән бәхәсләшеп торасым килми.* З.Зәйнуллин. *Табын янында да чакырылмаган кунак обком секретарена тирән мәгънәле карашлар ташлап алды, ул сүз буткасы куертмыйча, турыдантуры һөҗүмгә күчәргә кирәклеген әйтергә тели иде.* Р.Мирхәйдәров. *Ник дигәндә, бездә эш сүз буткасы куертудан узмый.* Татарстан яшьләре. **Сүз буткасы пешерү** 1) Бәйләнешсез яки мәгънәсе ачык булмаган сүзләр сөйләү. *Сорауның берниди фикергә корылмаган, кара мужикларның күзләренә төтен җибәрер өчен генә кайнатылган сүз буткасы икәнен бер шәкерт төшенеп өлгермәде ахры, каршы төште.* Ә.Фәйзи. *– Ярар, Сәлимә, сүз буткасы пешермә, чык, – диде Гөлфия.* Н.Гыйматдинова. *Ачу килгәндә шулай гына дип җиффәрә идек без аңа, бигрәк сүз буткасы пешерергә ярата иде дә соң.* Безнең гәҗит; 2) Эш урынына сүз белән мавыгу, күп сөйләү. *Җыелышны бик ошаттым... Чөнки артык сүз буткасы куерту булмады.* Ш.Камал. *Җил тегермәнен бушка әйләндерү кебек, бер мәсьәләдән икенчесенә күчә килеп, шактый сүз буткасы пешерелде.* Ф.Яхин. **Сүз буткасы ясау** *к.* **сүз буткасы пешерү**. *Шуңа күрә Русиядә пенсиягә чыгу яшен күтәрү турында сүз буткасы ясап вакыт үткәргәнче, картлык буенча хезмәт пенсияләрен күбрәк арттыру турында кайгырту хәерле.* Мәдәни җомга. **Сүзгә кешегә чыкмау** *к.* **сүз эзләп (өчен) кесәгә кермәү**. **Сүзгә килү** Ызгышу, талашу, уртак тел тапмау. *Диюнең аты белән сүзгә килүен Әйгәли күпер астында тыңлап утыра.* Әкият. *Килене белән сүзгә килсә, үзенең дә шундый хәлгә каласын ул яхшы аңлый иде.* М.Галәү. *Авылның ичмасам бер генә кешесе белән дә сүзгә килмәде, аны халык олылады.* М.Мәһдиев. **Сүзгә кысылу** Тиешле-тиешсез урында әңгәмәгә катнашу. *– Синең гениальный булмаган нәрсәң бармы соң, әзи, – дип сүзгә кысылыр Расих.* Җ.Юныс. *Клуб мөдире аларның кемнәр икәнен сораша башлады. Безгә барыбер иде, белмәгәч, сүзгә кысылмадык.* Р.Кәрами. *– Өстенә бастыгыз дисәң дә була, иптәш комиссар, ул егетне чормадан өстерәп төшердек, – дип сүзгә кысылды Хәйбри.* Ф.Сафин. **Сүздә генә калу** Сөйләнеп тә эшләнмәү, сөйләүдән узмау, тормышка ашмау. *Сүздә генә калмасын иде бу. Һәйкәлләр вәгъдәләрдән куелмый.* Г.Әпсәләмов. **Сүздән сүз китү** *к.* **сүз иярә сүз чыгу**. *Хисләр җырга күчә, дастаннарга, Кыйсса булып сүздән сүз китә.* Ф.Яхин. *Сүздән сүз китеп, Гыйльметдин абыйның дин юлына кайчан һәм ни рәвешле кереп китүе белән дә кызыксынасы иттем.* Ватаным Татарстан. **Сүздән сүз чыгу** *к.* **сүз иярә сүз чыгу**. *Шулай ятканда, сүздән сүз чыгып,*

*этләрнең тормышларыннан, көн күрмешләреннән күп сүзләр сөйләнде.* Г.Тукай. *Сүздән сүз чыгып, олпат язучыбыз гадәтенчә: «Ниләр язасың?» – дип кызыксынды.* Татарстан яшьләре. **Сүздән түбән** Бик түбән дәрәҗәдәге, бик начар сыйфатлы. *Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән; Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.* Г.Тукай. *Мине шулай сүздән түбән күрдеңмени?* М.Җәлил. *Мондый эшнең әхлак ягын, һәр сүздән түбән булганга, әйтеп тә тормыйм.* З.Мифтахов. **Сүздән чыкмау** 1) Тыңлаучан, күндәм булу. *Ә Сабир җизнәң шуннан соң гел минем сүздән чыкмады.* Р.Батулла. *Көннәрдән бер көн мәктәпкә килеп, шәкертләрне җыйнап кычкырына: «Мине губернатор куйды, минем сүздән чыкмагыз ---», – дип шаулап, стенага элеп куйган падиша портретын ала да идәнгә куя.* Гасырлар авазы; 2) Сүзне, вәгъдәне бозмау. *Аңа җавабында Зөһрә, әтием антыннан кире кайтса да, мин сүздән чыкмыйм, дип белдерә ---.* Дастан. **Сүзендә тору** Вәгъдәсен бозмау, алдамау; килешкәнчә, тиешенчә эшләү. *Кичен авылларына кайтырга җыенган кызга даруларны кертеп бирде дә: «Без бала-чага түгел, сүздә торабыз», – дип, машинага чыгып утырды.* Т.Галиуллин. **Сүзен итү** Вәгъдәсен үзенчә эшләү. *Саткай сүзен итте, тукталмады.* Г.Гыйльманов. *Закир белән Салих күпме әйтсәләр дә тыңламый, үз сүзен итә, алар белән бара.* В.Ильясов. *Үз сүзен итәсе килүме, шайтан суының тәэсире идеме – ир бүген танымаслык булып үзгәргән иде.* Казан утлары. **Сүзен сүз итү** Бернинди каршылыкларга карамастан, үз фикерен тормышка ашыру, үз дигәнендә тору. *Ни әйтсәң дә, үз дигәнен итеп, үз сүзен сүз итеп, тирә-якны тетрәтеп торган Борһан ла ул.* М.Хәсәнов. *Мансур Хәсәнов аның сүзен сүз итте, бөтенесен Бакый абзый теләгәнчә эшләтте.* Ф.Галимуллин. **Сүзен тоту** *к.* **сүзендә тору**. **Сүз җае белән** *к.* **сүз уңаеннан**. *Ул инде ярыйсы ук картайды да, ахрысы, аның кайнана булып түрдә утырасы, килен рәхәте күрәсе бик килә торгандыр; моны турыдан-туры әйтеп бетермәсә дә, сүз җае белән бик нык китереп-китереп чыгара.* Г.Ибраһимов. **Сүз җаенда** *к.* **сүз уңаеннан**. *Сүз җаенда әйтеп үтик: татар тел белемен үстерүгә зур өлеш керткән фидакяр галим М.Мөхәммәдиевкә багышлап чыгарылган җыентыкта бу сүзлек хакында болай дип язылган ---.* Ш.Асылгәрәев. *Сүз җаенда гел: «Мине фәлән кеше куйды, фәлән оешма куйды», – дип искә төшереп торалар.* Безнең гәҗит. **Сүз җилеме** 1) Сүз булсын өчен генә әйтелә торган сүз, сөйләм. *Сүз җилеме булсын дигән кебек, Илфар белән Кадим баштарак җыен вак-төякне сөйләшеп утырдылар.* Б.Камалов. *Күпме утырып та моның белән сөйләшергә сүз җилеме таба алмагач, Разил, бәллүр бокалны күтәреп, болай дип әйтә: «Әйдәле, дустым, бу дөньяда бер генә тапкыр яшибез».* Р.Вәлиев; 2) Тапкыр сүз; 3) Сүзне җанландырып җибәрү өчен, тапкыр, шаян әйтемнәр, сөйләмгә шаярту төсмере бирү алымы. **Сүз ияре сүз килү** *к.* **сүз ияре сүз чыгу**. *Сүз ияре сүз килеп, картның шүрлектәге төенчегенә дә чират җитте.* М.Галиев. **Сүз ияре сүз китү** *к.* **сүз ияре сүз чыгу**. *Сүз ияре сүз китте, --- һәммәсе дә телгә алынды.* Г.Бәширов. *Әнисе белән сөйләшеп утыра иделәр, сүз ияре сүз китеп, әллә ничек кенә бик җиңелдән әйтте дә куйды ул аны.* Ф.Яхин. *Фәрит кызны юмаларга кереште, сүз ияре сүз китте...* З.Мифтахов. **Сүз ияре сүз чыгу** Бер нәрсә турында сөйләгәндә, шуңа бәйле икенче, өченче нәрсәләр искә төшү, шуларга күчү. *Шуңа күрә инде олыгайгач та, сүз ияре сүз чыкканда: «Мин дөньяда ике ризык пешерә беләм: шуның берсе кабыклы бәрәңге, икенчесе, мин сиңа әйтим, парин, кабыклы йомырка», – дип, шушы сүзләреннән үзенә бер тәм табып сөйләр ие.* А.Хәсәнов. *Аерата фикердәшләр, ахирәт хатынкызлар утырганда сөйләшеп сүзләре бетмәс, сүз ияре сүз чыгар ---.* Г.Хөсәенов. **Сүз йөртү** Гайбәт тарату, берәүнең сүзен икенче кешегә җиткерү. *Даимән эше өйдән-өйгә сүз йөртүдә, үзе бик көнче хатын.* Ф.Халиди. *Бабаларыбыз да, кеше үтергән берне генә үтерә, сүз йөрткән меңне үтерә, дигәннәр...* Г.Гыйльманов. **Сүз кайтару** 1) Ризалашмыйча, каршы сүз әйтү, каршы килү, каршы кайтару. *Чыккан вакытта, күңелендә бер төрле хурлану, ачу килү хисе булса да, шул остазбикәнең сүз кайтаруы сөннәтче бабайның бәгъзе планнарыны бозса да, --- ул фикер берлән дә килешеп, түбән очта тегермәнче Фәхринең хатынына китте.* Г.Исхакый. *Иртәнге җиденче яртыда түгел, төн урталарында шалтыраткаһы булды – алай кырт кисеп сүз кайтармый иде.* Р.Вәлиев. *Әгәр теге әби каршы сүз кайтарган булса, иманым камил, сикереп торып сугып җибәрергә дә күп сорамас кебек тоелды ул кыз миңа.* Шәһри Казан; 2) Гомумән, җавап бирү. *Һи, бүкән, сүз кайтарырга телең бармыймыни?* К.Тинчурин. *Мин, яшемә буылып, аңа сүз кайтарып әйтә алмадым.* Ч.Айтматов. *Аңлыйсыздыр, бәлки, төшенмисез: Сүз кайтарып сорар чакмыни?* Ф.Яхин; 3) Үтенечне кире кагу, сүзне канәгатьләндермәү. *Мондый кеше өмә итсә, бик үк ялгыз булмаганнар сүз кайтарырга килештермиләр инде. --- Барабыз-барабыз, дип атылып торалар.* Г.Ибраһимов. **Сүз кату** *к.* **сүз кушу**. *Ничек дип эндәшергә, ничек сүз катырга белми йөдәгән иде шул, андый чакта бит аның теленә дә юньле-башлы сүз килми аптырата.* Р.Мөхәммәдиев. **---** *сөйләшергә ярата торган җыештыручы хатын Сания менә ничә көннәр инде Рәйханга сүз ката алмый йөрде.* Д.Каюмова. **Сүз килешү** Бер-берсен аңлау. *Алиш аның Казанда чактагы ук иптәше, сүз килешә торган кешесе иде.* Ш.Маннур. **Сүз көрәштерү** Бәхәсләшү. *Бәхәсләшергә бик ярата, сүз көрәштереп кешегә сүз бирмәүдән бик нык ләззәт таба торган иде.* Ш.Камал. *Киттем, син тозсыз белән сүз көрәштереп ябыгасым юк!* Н.Гыйматдинова. **Сүз куерту** Бер мәртәбә әйтелгән, аңлашылган фикерне яңадан кабатлау; артык күп сөйләшү, сүзне озайту. *Куштаннар хәйләкәр тегермәнчедән үзләренә тиешле өлешне алдылар, ахры, янгын турында бүтән сүз куертмадылар.* М.Галәү. *«Бала сабагын яхшы белә, дип, ни-*

*чек исбат итәсең!» – дип сүз куертты.* Х.Камалов. **Сүз куешу** Вәгъдәләшү. *Нуров белән мин берәр сәгатьтән очрашырга сүз куешкан идем.* А.Тимергалин. *Мин беркем белән дә очрашырга сүз куешмадым.* Г.Гыйльманов. **Сүз кушу** 1) Берәүгә эндәшү, сүз башлау. *Мәрьямбикә сүз кушмаса, Искәндәр дә, Гөлфәрваз да сүз башларлык сүз табудан тәмам гаҗиз иделәр.* К.Тинчурин. *Шунда берәр сүз әйтәсе иде бит, нindидер сүз кушып, бераз шаяртасы, көлдерәсе иде.* Г.Бәширов; 2) Тәкъдим ясау; сүз, сер салу. *Яратмасам, яучылар аркылы сүз кушмас идем.* Г.Толымбай. *Ирсез хатын, дип уйлагандыр инде, берничә тапкыр аулакта сүз кушып әрсезләнеп карады, кәнтәй.* Сөембикә. *– Шулай да, Шәүкәт абый, сезгә сүз кушучы хатын-кызлар булмый калмагандыр инде? – дип сорап куям мин.* Сәхнә. **Сүз кыстыру** Кеше сөйләгәндә, нинди дә булса берәр сүз өстәп, әйтеп кую. *– Оныттырырга теләсәләр, бигрәк тә онытылмый, – дип, хуҗа да сүз кыстырды.* М.Хәсәнов. *Үзалдына мыгырданып бер-ике сүз кыстырды Айрат Мәскүрә сөйләгәндә.* Ф.Яхин. **Сүзне бирмәү** 1) Сүздән кайтмау, әйткән сүзеннән чигенмәү. *Үҗәт күзен бирсә дә, сүзен бирмәс.* Мәкаль. *Икенчедән, башын кисмәгә бирсә дә, сүзен бирмәс әни, минем бу тырышлыгымнан кабынып китеп, яңа җәнҗал гына куптарыр дип курыктым.* Э.Шәрифуллина. *Бу – бәйгегә чакыру иде, һәм Флүр Сәхбиевич, сүзен бирәсе килмичә: – Мансур иптәш, сез – кунак, – диде.* Р.Кәрами; 2) Бәхәстә, сүз көрәштерүдә җиңелмәү. *Һәммәсендә дә, бик озакка сузып сүз бирмәсә дә, эченнән җиңелгәнене хис итте.* Г.Исхакый. *Бәхәсләшергә бик ярата, сүз көрәштереп кешегә сүз бирмәүдән бик нык ләззәт таба торган иде.* Ш.Камал. **Сүз өчен генә** *к.* **сүз булсын дип**. **Сүз рәте белән** *к.* **сүз уңаеннан**. **Сүз рәтендә** *к.* **сүз уңаеннан**. *Сүз рәтендә бер сүз әйтәм, туктагыз!* Ш.Бабич. **Сүз салу** Нәрсәгә дә булса өндәп, сорап сүз кушу; тәкъдим ясау. *Шаһ Тимергә сүз салды.* Дастан. *Әни күңеле йомшак була, Сәкинә үтенеп, хәтта елардай хәлдә сорагач, Габдулла абзыйга сүз салып караган иде ---.* Л.-Х.Таналин. *Аннан читтә калмас өчен, алар бәпкәләре күп булган апаларга җәйдән үк сүз салып куйганнар.* Татар халык иҗаты. **Сүз уңае белән** *к.* **сүз уңаеннан**. *Сүз уңае белән аланнарның Төньяк Кавказ һәм Азов яны далаларында яшәүче, иран телле кабиләләр булуын әйтергә кирәк.* Р.Фәхретдинов. **Сүз уңаенда** *к.* **сүз уңаеннан**. *Сүз уңаенда әйтергә кирәк: «Гармун сөйләр»дәге төсле, музыканы уенга механистик ябыштырып кую бер дә кызыклы түгел.* М.Җәлил. **Сүз уңаеннан** Сүз арасында, башка мәсьәләләр белән берррәттән. *Бер дустым әйтмешли, үзең каралып бетсәң дә халыкны агартырга чыгып китәсең. Зарланып әйтүем түгел, сүз уңаеннан гына...* Р.Кәрами. **Сүз эзләп кесәгә кермәү** Сүзгә, җавапка оста, тапкыр булу. *Үзе сокланган табигать күренешләренә башкаларны да сокландырырга тырышканда сүз эзләп кесәгә керми инде Мөнәвәр карт.* Ф.Хөсни. *Яшьрәк чакта җаваплы эшләрдә эшләп, Советлар илен аркылы да, буйга да кичкән кеше булганга, бервакытта да сүз эзләп кесәгә керми, бер сорауны да җавапсыз калдырмый.* Шәһри Казан. **Сүз эзләп кешегә кермәү** *к.* **сүз эзләп кесәгә кермәү**. **Сүз эзләп күршегә кермәү** *к.* **сүз эзләп кесәгә кермәү**. *Галимулла аптыраулы хәлгә калган иде, сүз эзләп күршегә керми торган кеше турыдан бәрә, ул да шулай эшләде, ярды да салды: – Мин өйләнәмме, синме?* Ф.Яхин. **Сүз эштән аерылмау** Әйткән сүзендә, вәгъдәсендә тору, вәгъдәле булу. *Тege, кем әйтмешли, сүзебез эштән аерылмый: ничек әйтсәк, шулай эчәбез.* Н.Акмал. *Быелгы катлаулы шартларда алты миллион тоннадан артык уңыш җыеп ала алган авыл хезмәтчәннәренең сүзләре эштән аерылмый.* Ватаным Татарстан. **Сүз югында сүз булсын дип** *к.* **сүз булсын дип**. *Эш арасында да, капка төбендә утырганда да, сүз югында сүз булсын дигәндәй, гел шул турыда сөйләшеп алалар ---.* Р.Батулла. *«Сүз югында сүз булсын: ата казыгыз күкәй саламы?» дигән сымандрак тоелды.* Р.Кәрами. *«Өегез җылы икән» булды, сүз югында сүз булсын, исәнме кодагый, дигәндәй әйткән беренче сүзе.* Р.Мөхәммәдиев. **Сүз югында сүз булсын өчен** *к.* **сүз булсын дип**. **Сүз югыннан сүз булсын өчен** *к.* **сүз булсын дип**. *Ул эче пошканнан, сүз югыннан сүз булсын өчен һәм дә Гыйльманов нәрсә әйтер икән дип, үз-үзенә сөйләгән була ---.* Ш.Камал. **Сүз юктан сүз булсын дип** *к.* **сүз булсын дип**. *Барый мәхдүм, сүз юктан сүз булсын дигәндәй, Мостафа байдан хәл-әхвәл сорашып утырды ---.* М.Галәү. *Гадәти тәгъбирләр белән хәл-әхвәл сорашкач, мин, сүз юктан сүз булсын дигән кебегрәк: – Эштә түгелмени? – дип сорадым.* Ф.Шәфигуллин. *Сүз юктан сүз булсын дип сөйли бу.* Г.Гыйльманов. **Сүз ялгану** Әңгәмә җайга салыну, уртак тел табылу. *Кунакны ялгыз калдырмас өчен, Илһамга Камил абыйсы тирәсендә булырга кушты. Ләкин ике арада сүз ялганмады.* М.Галиев

**СҮЗӘНӘ** *и. фар.* Бизәк буларак стенага эленә торган чигүле тукыма

**СЎЗ БАШЫ** *и. махс.* Берәр әсәргә язылган кереш сүз, китап алдындагы кереш мәкалә. *1931 елны Һади Такташ үзенең шигырь һәм поэмаларының сайланмасын җыйнап, күренекле тәнкыйтьче Гомәр Галинең сүз башы белән --- дөньяга чыгарды.* Р.Ишморат. *Беренче том зур һәм эчтәлекле сүз башы белән ачыла.* Ш.Асылгәрәев

**СҮЗГӘ́-СҮЗ** *рәв.* 1) Дөп-дөрес һәм төп-төгәл, бер сүзен дә төшереп калдырмыйча; сүзен сүзгә. *Табында катнашкан илчеләрнең берсе ике арада барган сөйләшүне сүзгә-сүз диярлек куен дәфтәренә теркәп бара.* М.Хәбибуллин. *Тәкъдимне ишетеп куанган гыйлем иябез, кесәсеннән кульязма белән гәзитә чыгарып, кичәге хикәятен сүзгә-сүз сөйләп бирде.* Р.Вәлиев

2) Тәрҗемә ителгән текстның һәр сүзен һәм эзлеклелек тәртибен төгәл саклап; сүзен сүзгә, формаль, механик рәвештә. *Мин аларга шигырьләремнең сүзгә-сүз тәрҗемәсен калдырдым ---.* М.Җәлил. *Сүзгә-сүз тәрҗемә ысулы төрле телләр һәм төрле материаллар тәрҗемәләрендә кулланыла.* Р.Йосыпов

**СҮ́З ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Бер генә сүздән торган җөмлә. *Башка сүзләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләр белән бирелгән җөмләләр сүз җөмләләр дип атала.* М.Зәкиев. *Сүз җөмләләрне җөмләнең аерым бер кисәгенә тиңләп булмый, ягъни аны ия, хәбәр яки кайсы да булса бер иярчен кисәк дип атау мөмкин түгел.* Татар грамматикасы

**СҮЗЛӘП** *рәв.* Сүзләр рәвешендә; сүз итеп; һәр сүзне аерым-аерым әйтеп. *Иҗекләп укудан әкренләп йөгерек, аңлап, сүзләп укуга күчү.* Фән һәм тел. *Алар иҗекләп укый, мин – сүзләп.* Татарстан яшьләре

**СҮЗЛӘШҮ** *ф.* 1) Каршы әйтү, әрепләшү. – *Чамасын белергә кирәк! – дип сүзләште Гүзәлия.* Казан утлары

2) Ызгышу, сүзгә килешү. *Бу юлы инде сезләргә князьнең үзләре берлән сүзләшергә туры килер!* Р.Батулла. *Беләм, мине ташламыйсың, Ялганлама, яратмыйм. Сүзләшеп без аерылышмыйк, Усаллыкка бара алмыйм.* Н.Абдулкәримова

**Сүзләшә башлау** Сүзләшергә тотыну

**Сүзләшеп китү** Кинәттән сүзләшү. *Шау-шуы да була язып калды: һич тә көтмәгән-уйламаган кешеләр сүзләшеп киттеләр.* М.Хәсәнов

**Сүзләшеп тору** Һәрвакыт яисә әле, хәзер сүзләшү

**СҮЗЛЕ** *с.*1) Телдә яңгыратылган, язылмаган. *Сүзле формада бирелгән*

2) *сир.* Күп сөйләшергә яратучан; сүзчән. *Сүзле әбекәй*

3) Гаугалы, тавышлы. *Бик сүзле булды бу эш*

4) *махс.* Көе генә түгел, сүзләре, тексты да булган. *Сүзле музыкалардан тыш, җыентык ахырында, фортепианода башкару өчен, өч инструменталь (уен коралында башкара торган) әсәр бирелде.* М.Җәлил. *Татарстан радиосы һәм телевидение дә һәр иртәне сүзле гимн белән башлап җибәрер.* Татарстан яшьләре

**СҮЗЛЕК** *и.* 1) Сүзләрнең, тотрыклы сүзтезмәләрнең аңлатмаларын, мәгънәләрен, башка телгә тәрҗемәләрен һ.б.ш.ны җыеп, алфавит тәртибе белән яки бүтәнчә урнаштырып биргән белешмәлек, китап. *Аңлатмалы сүзлек «кендек» сүзенең берничә мәгънәсен күрсәтеп үтә.* Ф.Урманче. *Сүзлек татар теленең барлык диалектлары буенча тупланган якынча 40000 берәмлекне эченә ала.* Фән һәм тел

2) Берәр телнең, язучының яки әсәрнең барлык сүзләре, сүз байлыгы; лексика. *Аларның текстында безнең телнең әлегә хәтле өйрәнелмәгән гаять бай сүзлек фонды ята.* Н.Исәнбәт. *Менә шундый авыр, буталчык заманда, мәсьәләнең тагын да кискенләшкән чорында Җ.Вәлиди үз өстенә татар әдәби телен өйрәнеп, аның грамматикасын язу, телебезнең сүзлек байлыгын туплап, аның тулы сүзлеген төзү бурычын йөкли.* Ш.Асылгәрәев

**СҮЗЛЕКЧӘ** *и.* 1) Мөстәкыйль яки берәр әдәби әсәргә, фәнни хезмәткә һ.б.ш.га кушымта буларак бирелгән кечкенә сүзлек. *К.Насыйри китабының ахырында шул китапка мөнәсәбәтле сүзлекчә дә бирелгән.* Г.Галиуллина. *Меңьеллык алдыннан һәр милиция хезмәткәренә, туристлар белән аралашу өчен, сүзлекчәләр таратылган иде.* Идел

2) Сүзлектә аңлатылган барлык баш сүзләрнең исемлеге; лөгатьлек. *Нәкъ шул вакытта Э.Г.Улумбәков ярдәме белән Татар энциклопедия сүзлекчәсенең өч телдәге 20 битле беренче үрнәге эшләнде.* Гыйлем хәзинәсе. *Мәкаләләр язу эшенә 500 автор тартыла, сүзлекчә 65 мең мәкаләне эченә ала.* Фәнни Татарстан

**СҮЗЛЕКЧЕ** *и.* Сүзлек төзүче, сүзлек белгече; лексикограф. *Тел галиме буларак Г.Нугайбәк сүзлекләр төзү белән дә шөгыльләнә, сүзлекчеләр төркеме белән дә җитәкчелек итә.* Фән һәм тел. *Институт сүзлекчеләре татар теленең орфографик сүзлеген төзү өчен материал туплый башладылар. Сүзлекче кадрлар хәзерләү*

**СҮЗЛЕКЧЕЛЕК** *и.* Сүзлек төзү эше; сүзлекләр төзү турындагы фән тармагы. *Инсани тикшеренүләрнең барлык мөһим тармаклары: фундаменталь тел гыйлеме, сүзлекчелек, диалектология, әдәбият фәне, текстология, --- театр гыйлеме, тасвири һәм музыкаль сәнгать – менә күпме тармак һәм өлкәләрне берләштерә әлеге гыйльми комплекс.* Ватаным Татарстан

**СҮЗМӘ́-СҮЗ** *рәв. к.* **сүзгә-сүз**. *Укыганны сүзмә-сүз сөйләп бирү. Сүзмә-сүз тәрҗемә*

**СҮЗСЕЗ** *с.* **1.** 1) Сөйләшми, дәшми торган, сүзгә катнашмаган. *Шигырьләрне укыганда, күз алдында тын һәм һәрбер сүзне аңлап калырга омтылган сүзсез залны күрәсең.* Һ.Такташ. *Мондагы үзгәреш-яңалыкка шаккатып өлгерерлек түгел, шуңа да сүзсез Ирекнең исе китмәде.* Р.Мулланурова

2) Күп сөйләргә гадәтләнмәгән, аз сүзле. *Еллар үтү белән, Рәхим үз эченә бикләнгән сүзсез бәндәгә әверелде.* Г.Гобәй. *Ире акыллы, эшчән, сүзсез һәм хатын кадерен белә торган иде.* М.Мәһдиев. *Сабыр, сүзсез кеше иде ул мәрхүм Сафуан абый.* Р.Батулла

3) Каршы әйтергә гадәтләнмәгән, күндәм, карусыз. *Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, кара эшкә гаҗәп батыр иде.* Г.Ибраһимов. *Ә марҗасы кырында басып торган сүзсез Иван я Пётр шат.* З.Зәйнуллин. *Авылныкылар оялчан, сүзсез, кыюсыз, шәһәрнекеләр исә чатнап торалар иде.* Х.Ширмән

4) Сөйләмичә генә уйнала-башкарыла торган. *Туй күренешенә безне сүзсез рольләргә чыгардылар.* Р.Батулла. *Сүзсез күренешләрдә катнашу*

5) Сүзләре-тексты булмаган, көй рәвешендә генә җырлана-уйнала торган. *Аркадий Ильич Островский көенә «Мин бик шат, чөнки мин, ниһаять, өемә кайтам» исемле сүзсез җыр (вокализ) башкарып, Эдуард Хиль үз вакытында дан казанды.* В.Нуруллин. *Ул, үз-үзен онытып, сүзсез моң тәэсиренә бирелде.* М.Галиев. *Борынгы заманда, бәлки, беренче сүзсез музыка тугандыр.* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сүзләр әйтмичә, дәшмичә, сөйләшмичә. *Күптәнге якын танышлар башта сүзсез эшләделәр.* А.Алиш. *Бертын сүзсез торгач, агайэне буылып көләргә керешә.* М.Кәрим. *Аралар якын булса да, Сүзсез бару күңелсез.* Ф.Яруллин

2) Каршылык күрсәтмичә. *Бу ике көчнең соңгысы җиңәчәген күңелем бик*

*ачык сизсә дә, мин сүзсез генә бирелергә теләмәдем.* М.Әмир. *Патша Александр I һөҗүмгә дигәч, Кутузов каршы чыкмый, сүзсез риза була.* З.Зәйнуллин

3) Вакчылланмыйча, төпченмичә, бик тиз килешеп. *Бу бәетләрне урамнарда кычкырып җырлап йөри башлагач, ике як та сүзсез, әллә нинди мәһәрләр-фәләннәр турында сөйләшеп тормыйча ук, безне өйләндермәкчеләр иде.* Г.Ибраһимов

**СҮЗСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Аз сөйләшүчән булып китү, аз сүзлегә әйләнү. *Корбангали абзый, юлга чыккач, телен йоткандай булып сүзсезләнә.* Ф.Хөсни. *Армиядән тәмам ябыгып, төссезләнеп, сүзсезләнеп кайтты.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Сүзсезләнә бару** Торган саен ныграк сүзсезләнү

**Сүзсезләнә төшү** Беркадәр сүзсезләнү

**Сүзсезләнеп калу** Нинди дә булса хәл-тәэсирдән соң сүзсезләнү. *Боегып, сүзсезләнеп калдым.* Ф.Яхин

**Сүзсезләнеп китү** Соңгы арада сүзсезләнү

**СҮЗСЕЗЛЕК** *и.* 1) Аз сүзле булу, күп сөйләргә яратмаучанлык. *Кружкаларны бер-ике күтәргәч ---, телләребез ачылды. Хәтта сүзсезлеге, дөресе, бик аз сүзле булуы белән дан алган ефрейтор Сәмигуллин да --- нәрсәдер сөйләп алды.* А.Шамов. *Бу сүзсезлектә кавышу куанычы да, югалтулар аянычы да бар иде.* Р.Батулла

2) Бәхәсләшергә, әрепләшергә гадәтләнмәгәнлек, күндәмлек, карусызлык. *Татарны сүз белән түгел, сүзсезлек белән җиңәргә мөмкин.* Ф.Яхин

3) Сөйләми-сөйләшми тору, дәшмәү, тынлык саклау хәле. *Булат сеңлесенең такылдавын бүлдерде дә шунда сүзсезлектән, эшсезлектән кыенсынып, газапланып утырган Җиһангирга борылды.* Г.Ибраһимов. *Аның сүзсезлеге, барча төрле хөкемнәрне дә кабул итәмен дигәндәй, башын түбән салындыруы җыелышның максатлы һәм төгәл тәртип белән төзелүенә, алып барылуына бәйле иде.* Ф.Яхин

**СҮ́З УЙНАТУ** *ф.* 1) *әд.* Охшаш яңгырашлы бер яки берничә сүзне яки сүзтезмәне бер үк контекст эчендә төрле мәгънәләрдә куллану; каламбур. *Сүз уйнату матур әдәбиятта, бигрәк тә поэзиядә, еш кулланыла: Кара әле, кара, Каен яфрак яра, Каюм утын яра, Кулларында яра.* Г.Галиуллина. *Әгәр әле бер генә шигырьдә шундый юллар очратсак, гап-гади бер очраклылык, сүз уйнату дип уйларга булыр иде.* Р.Рахман

2) Шаяртып, уен-көлке белән сөйләшү. *1922–1925 елларда җәй көне ул бирегә коляскасы белән чыгып утыра, яшь-җилкенчәк, бигрәк тә кызлар белән уратып алынган килеш рәхәтләнеп шаярта, сүз уйната.* Р.Әмирхан. *– Житте, җитте! – диде Хәлим, чатнаган башын тотып, – минем сүз уйнатып торырлык теләгем дә, хәлем дә юк.* З.Мәхмүди

3) *күч.* Матур, купшы, ләкин сөйләмнең эчтәлеге өчен әллә ни әһәмияте булмаган сүзләр белән мавыгу. *Шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде.* Һ.Такташ

4) *күч.* Күперенке буш сүзләр белән төп теманы читләтеп үтәргә тырышу. *Кыз әле болай боргаланды, әле тегеләй сүз уйнатты.* С.Рафиков. *– Болар бары да сүз уйнату, сәбәп эзләү генә, иптәш директор, – диде Иштуган.* Г.Әпсәләмов

**СҮЗЧӘН** *с.* 1) Күп сөйләргә яратучан, сөйләмчәк. *Ә сүзчән карт сөйләнә бирде ---.* М.Галәү. *Утә ачык чырайлы сүзчән кешеләр булып чыктылар болар ---.* Ф.Хөсни. *Квартира апасы бик сүзчән булып чыкты, җитмәсә, бераз саңгырау.* С.Сөләйманова

2) Бәхәсләшергә, әрепләшергә яратучан

**СҮЗЧӘНЛӘНҮ** *ф.* Сүзчәнгә әйләнү, сүзчән булып китү. *Мәрьям беренче булып сүз башламасын өчен, «серен» һаман саклап торсын өчен ул, кинәт кенә сүзчәнләнеп: – Беләсеңме, җыелышта нәрсә турында суган саттылар, – диде.* Н.Фәттах. *Холкы да үзгәреп киткәндәй булды: басынкылыгы, салмаклыгы онытылды, сүзчәнләнде, хәрәкәтләре җитезләнде ---.* Л.Ихсанова

**Сүзчәнләнә бару** Торган саен ныграк сүзчәнләнү. *Фидан моны сизә, сизгән саен ныграк сүзчәнләнә бара, аңа ошарга тырыша.* Р.Вәлиев

**Сүзчәнләнә төшү** Беркадәр сүзчәнләнү. *Бераздан иркен рәвештә сөйләшеп утыра башлый, хәтта гадәттәгегә караганда да сүзчәнләнә төшә.* И.Нуруллин

**Сүзчәнләнеп китү** Билгеле моменттан алып сүзчәнләнү. *Айнык чагында бик аз сөйләшә торган яшь бабай, бераз салып алгач, шулай кирәгеннән артык сүзчәнләнеп китә иде.* Н.Фәттах. *Кешеләр сүзчәнләнеп китәләр, үз мәшәкатьләрен онытып, азга гына шул яңалык белән яшәп алалар.* М.Галиев

**СҮЗЧӘНЛЕК** *и.* Сөйләшергә ярату, күпсүзлелек, телдәрлек. Сүзчән кешегә хас сыйфатлар, сүзчән булу. *Мин үзем сүзчән егет. Сүзчәнлегем өчен бәлагә дә эләктем.* К.Нәҗми. *Ул --- эштә кулдашлары куерткан әңгәмәгә дә сирәк кушыла, үз эченә бикләнгән үк кеше булмаса да, сүзчәнлекне өнәми.* М.Хуҗин

**СҮ́ЗЬЯСАГЫЧ** *с.* Сүз ясый торган, сүз ясау өчен хезмәт итә торган. *Шул закончалыклар катнашында һәм сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә татар телендә аерым сүзләр ясала.* И.Низамов

**СҮ́ЗЬЯСАЛЫШ** *и. лингв.* 1) Телнең сүз ясау чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы. *Сүзьясалышында продуктив кушымчалар белән беррәттән продуктивлыгын югалтканнары да бар.* Ф.Хисамова. *Ф.Ганиев хезмәтләрендә татар телендә сүзьясалыш проблемалары төрле яклап җентекләп тикшерелгән, шул исәптән кушымчалау ысулы белән сүзьясалышның барлык модельләре дә анализланган.* М.Нигъмәтуллов

2) Тел белеме кысаларында яңа сүзләрнең ясалыш закончалыкларын һәм ысулларын өйрәнә торган тармак. *Хәзер татар теленең грамматик төзелеше дигән вакытта морфемика, морфонология, сүзьясалыш, морфология һәм синтаксис дигән биш тармак яктыртылуын истә тотабыз.* И.Бәширова. *Татар грамматикасы тармаклары арасында сүзьясалыш фәне иң соңгыларының берсе булып формалашты.* М.Нигъмәтуллов

**СҮЛ** *и.* Тере организм күзәнәкләрендәге, күзәнәк араларындагы, тукымаларындагы, әгъзаларындагы сыекча.

*Кечкенә ике ярадан кан сүле белән бергә әллә нинди кап-кара төерләр чыкты.* З.Мурсиев. --- *агачтагы туклыклы сүл киселгән урыныннан агарга мөмкин.* Ватаным Татарстан

**СҮЛӘМӘ** *и. хим.* Суда, спиртта, эфирда, ацетонда эри торган ак матдә; көчле агу; терекөмеш хлориды

**СҮЛЛӘНҮ** *ф.* Сүл барлыкка килү; сүле күбәю, арту

**Сүлләнә башлау** Сүлләнергә тотыну

**Сүлләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта сүлләнү. *Аның балтыр сөягендәге иске ярасы ачылган, эренләп, сүлләнеп тора.* Х.Камалов

**СҮЛЛЕ** *с.* 1) Сүле булган. *Ит – сүлле, егет җилле була.* Мәкаль. *Ярасы сүлле иде, тиз купты.* М.Рәфыйков

2) Сүл белән аралашкан, сүл катнашкан

**СҮЛПӘН** *с.* **1.** 1) Баш-башыннан тарттырылмаган, буш, салынып торган. *Сүлпән бауга эленгән керләр җиргә кадәр салынган*

2) Нык бөтерелмәгән, тыгызлыгы җитмәгән, чирак булмаган. *Сүлпән җептән бәйләнгән бияләй. Сүлпән бау*

3) Бик әкрен; җитез түгел. *Тик без генә – тоткыннар гына сүлпән.* И.Салахов. *Моңарчы егетнең уйнавы ничектер сүлпәнрәк иде.* Р.Кәрами. *Аның тавышы зәгыйфь, хәрәкәтләре сүлпән булдылар.* Ф.Яхин. *Абыебызның адымы сүлпән иде.* Л.Гыймадиева

4) Басынкы, ихтыярсыз, кыюсыз. *Урамыбызда иң тыныч, иң сүлпән, иң шапшак хатын Мәрхәбә кодагый иде.* М.Кәрим. *Газимә, ничектер, бик сүлпән иде, кыюсыз иде.* Н.Фәттах

5) Кәефсезлекне, битарафлыкны белдерә торган. *Кадыйрның сүлпән йөзе кинәт яктырып китте, күзләрендә серле очкыннар җемелдәде.* М.Галәү. *Уйнаттың син, гармун, уйнаттың Йоклап яткан сүлпән күңелне.* Х.Туфан. *Сәләхинең тавышы сүлпән иде.* Н.Хәсәнов

6) Кызу түгел, эсселеге түбән; сүрән (*1 мәгъ.*). *Баеп баручы кояшның сүлпән нурларына коенып, сибеп ташлаган терекөмеш бөртекләре кебек күлләр, кибәнле болыннар --- алсу-кызгылт нурга чумган иде.* Д.Каюмова. *Бүрттерелгән дөгене шулар өстенә салып, бераз шулпа өстиләр дә, өстен каплап, сүрән утта болгатмыйча гына 1–1,5 сәгать томалап пешерәләр.* Минем йорт

**2.** *рәв. мәгъ.* Әкрен генә, салмак темп белән, кызу түгел. *Язгы базарларда да халык күп була, әмма сәүдә сүлпән бара, сатып алучы бөтенләй юк диярлек.* М.Галәү. *Янәшә утырышкач, Гасыйм Сәләхович, күрешергә килгән ир буларак, башлап үзе сүлпән генә сорады ---.* Ә.Еники

**СҮЛПӘНӘЙТҮ** *ф. к.* **сүлпәнләндерү**. *Эш темпын сүлпәнәйтергә ярамый*

**СҮЛПӘНӘЮ** *ф. к.* **сүлпәнләнү**. *Ләкин соңгы елларда сез театрга кайткач, ул ни өчендер үзгәрде... режиссёр буларак та эшләве сүлпәнәйде... сәбәбен әйтә алмыйм...* Р.Батулла. *Андый вакытта төрле кеше үзен төрлечә тота: берәүләр эчүгә сабыша, икенчеләр эшендә сүлпәнәя.* Р.Кәрами

**Сүлпәнәеп алу** *к.* **сүлпәнләнеп алу**. *Биш-алты ел аралыгында Казахстанда кино сәнгате берникадәр сүлпәнәеп алды.* Ватаным Татарстан

**Сүлпәнәеп бару** *к.* **сүлпәнләнеп бару**. --- *Фәрит Нәбиуллин бирелә ике ел гына эшләсә дә, соңгы елларда сүлпәнәеп барган эш темпларын җанландырып җибәргән.* Ватаным Татарстан

**Сүлпәнәеп бетү** *к.* **сүлпәнләнеп бетү**

**Сүлпәнәеп калу** *к.* **сүлпәнләнеп калу**. *Кинәт барысы да сүлпәнәеп калдылар.* Д.Булатова

**Сүлпәнәеп китү** *к.* **сүлпәнләнеп китү**. *Шунысын да әйтергә кирәк: Чемпионнар лигасында чыгыш ясый башлагач, «Рубин» ил беренчелегендә берникадәр сүлпәнәеп китте.* Татарстан яшьләре

**Сүлпәнәеп тору** *к.* **сүлпәнләнеп тору**

**Сүлпәнәя бару** *к.* **сүлпәнләнә бару**. *Белгечләр фикеренчә, Анкараның Мәскәүгә тартылуының беренче сәбәбе – Төркияне Европа берлегенә кабул итү мөмкинлегенең сүлпәнәя баруы.* Мәдәни җомга

**Сүлпәнәя башлау** *к.* **сүлпәнләнә башлау**. *Яшь барган саен, кешеләрдә кан куеру күзәтелә, 35 яшьтән алып матдәләр алмашы сүлпәнәя башлый.* Шәһри Казан

**Сүлпәнәя төшү** *к.* **сүлпәнләнә төшү**. *Ә соңгы араларда бу эшләр бераз сүлпәнәя төште кебек.* Р.Вәлиев. *Революцион рух сүлпәнәя төшкәч, царизм демократик матбугатка карата катгый һөҗүмгә күчә.* Гасырлар авазы

**СҮЛПӘНЛӘНДЕРҮ** *ф.* Сүлпәнгә әйләндерү; кемнең яки нәрсәнең дә булса хәрәкәтен, тизлеген, җитезлеген киметү; акрынайту. *Рөхсәт алгач, Камалов башта югалып калды: хастаханәдә озак яту кешене сүлпәнләндерә, йомшарта; ләкин ул үзен бик тиз кулга алды.* Р.Мирхәйдәров

**Сүлпәнләндерә башлау** Сүлпәнләндерергә тотыну

**Сүлпәнләндереп карау** Булу-булмавын тикшерү-сынау өчен сүлпәнләндерү

**Сүлпәнләндереп тору** Күпмедер вакыт сүлпәнләндерү; даими сүлпәнләндерү

**СҮЛПӘНЛӘНҮ** *ф.* Сүлпәнгә әйләнү; нәрсәнең дә булса тизлеге, активлыгы кимү. *Шаулап барган эш сүлпәнләнде.* Р.Батулла. *Карашы сүлпәнләнгән, күзләрен аска төшергән, --- мескенләнеп калган кызга карагач, егет аны җәлләде.* Р.Кәрами. *Сүлпәнләнгән учактан сирпелгән тоныкут шәүләсе Җәббарның йөзендә уйнаклады.* Н.Гыйматдинова

**Сүлпәнләнә бару** *к.* **сүлпәнләнеп бару**. *Беренче акттан соңгы картиналар барысы да сүлпәнләнә генә баралар.* М.Җәлил. *Шулай да аның көннән-көн сүлпәнләнә баруын, ыру эшләре --- белән бик үк кызыксынмый башлавын якын кешеләре күрми калмадылар.* Н.Фәттах

**Сүлпәнләнә башлау** Сүлпәнләнүе сизелү. *Педуниверситет укытучысы Резеда Садыйкова соңгы вакытта Ульяновскида милли хәрәкәтнең сүлпәнләнә башлавы хакында борчылып сөйләде.* Ак калфак

**Сүлпәнләнә төшү** Бераз, беркадәр сүлпәнләнү. *Халык инде сүлпәнләнә төшкән, артык кычкырып та сөйләшми, уенчак сүзләр дә кимегән иде.* А.Тимергалин. *Без 2007–2009 еллар тәҗрибәсенә йөз тотып эшлибез, ул вакытларда торак базары яңа елдан сүлпәнләнә төшә иде.* Р.Вәлиев

**Сүлпәнләнеп алу** Кыска вакытка, бераз гына сүлпәнләнү. *Агитбригада эше сүлпәнләнеп алган җирләр дә булды, әмма «юлдаш»ларның эшчәнлеге туктап тормады.* Шәһри Казан

**Сүлпәнләнеп бару** Аз-азлап, акрынлап сүлпәнләнү. *Казанның башка югары уку йортларында техник белгечлекләргә татарча укыту сүлпәнләнә барганда, КДАТУда бу эш сүнмичә дәвам итә.* Фән һәм тел. *Авыл халкы үзе дә нигәдер сүлпәнләнеп бара бугай.* Туганайлар

**Сүлпәнләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй сүлпәнләнү. *Аның сүзләренчә, --- объектлар төзелешенә акча бирелсә дә, эшләү теләге зур булса да, озак еллар буена сүлпәнләнеп беткән төзелеш эшләренә җан өрү үтә авыр булып чыккан.* Казан утлары

**Сүлпәнләнеп калу** Нindидер йогынтыдан, күпмедер вакыттан соң сүлпәнләнү. *Бала табуга, Сания – терекөмеш кебек җитез, дәртле хатын – кинәт кенә сүрелеп, сүлпәнләнеп кала.* Г.Гыйльманов. *Илнең театр эшлекләре берлеге карары белән --- төрки халыклар фестивале башта Урта Азия республикалары һәм Казакъстанда биш ел рәттән үткәрелә килеп, союздаш республикалар таркалганнан соң сүлпәнләнеп, тараеп калган иде.* Тамаша

**Сүлпәнләнеп китү** Кинәт сүлпәнәю. *Сүлпәнләнеп китсә: «Җилдерәсе минутларың алда әле, Буяным, сабыр ит», – дип тынычландырып, төрлечә сынады.* М.Шабай

**Сүлпәнләнеп тору** Әле, хәзер сүлпән булып күренү, вакытлыча сүлпәнләнү

**СҮЛПӘНЛЕК** *и.* 1) Сүлпән (*1–2 мәгъ.*) булу сыйфаты, рәвеше. *Җепнең сүлпәнлеге*

2) Әкренлек, артык тынычлык. *Әле иртәнге алты гына булса да, хәзер аның йокысы да, сүлпәнлеге дә качкан иде.* А.Расих

3) Төшенкелек, күңелсезлек; битарафлык. *Киресенчә, әллә нинди мена җан бушлыгы, җан сүлпәнлеге тойган кебек...* Ә.Еники. *Тора-тора Ларисаның да сүлпәнлеге югала, ул да Булаттан ким шатланмый сыман.* М.Вәлиев

**СҮНДЕРГЕЧ** *и.* Ут сүндерү җайланмасы. *Тирә-юньне ут вулканы чолгап алырга әзер торган. Янгын сүндергеч бомбалар аскан самолётлар, вертолётлар тәүлекләр буе Марково күгендә очып йөргәннәр.* Ә.Маликов. *Йортның эчке электр җиһазлары карап тикшереп чыгылмаган: подъездда чыбыклар асылынган, төрлечә ялганган, сүндергечләр ватык.* Шәһри Казан

**СҮНДЕРЕЛҮ** *ф. кайт. юн. к.* **сүндерү**. *Таң алдыннан янгын сүндерелде.* Р.Кәрами

**СҮНДЕРЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **сүндерү**. *Бәлки, лесничий Раил белән Мәлихнең ут сүндерешергә бармавына игътибар да итмәгәндер.* Р.Кәрами

**СҮНДЕРҮ** *ф.* 1) Янудан, көйрәүдән, көюдән, пыскудан туктату. *Альберт иңнәрен сикертеп алды, төпчеген сүндереп, чүп савытына илтеп ташлады.* А.Тимергалин. *Шәмне сүндереп, күз ачып йомганчы караңгылыкка кереп яшеренер төсле иде ул.* Р.Вәлиев

2) Электр яки яну матдәләре белән эшли торган аппаратларны һ.б.ш.ларны эшләүдән туктату. *Комбайнчы аның тавышын ишетеп, моторны сүндергән арада, Әбүзәр --- огнетушительгә тотынды.* Р.Кәрами. *Ни эшлисең инде, булмагач булмый, компьютерны сүндереп кайтып китәсе генә калды.* З.Мурсиев

3) *махс.* Тәэсир көчен, куәтен киметү; басу. *Тавышны сүндерү*

4) *махс.* Известь, сода кебек матдәләрнең, су, серкә кушып, химик активлыгын киметү

5) *күч.* Бетерү, юкка чыгару, басу. *Көнләшү ул мәхәббәтне, киләчәкне үтерә, бергә булу теләген сүндерә.* Ф.Ярулин. *Куркынып, әмма андый афәтнең килмәвен теләп көттем. Һәм бу куркыну минем бик күп нәрсәгә дәртемне сүндерде.* Э.Шәрифуллина

**Сүндерә башлау** Сүндерергә тотыну. *Менә кинәт аждаһа төсле бер нәрсә сызгырды да йолдызларны сүндерә башлады.* Әкият. *– Юк, мин уйнап туйганмын, – дип, Алик салкын гына җавап бирде һәм шлемны сүндерә башлады.* Асылъяр

**Сүндерә килү** Электән үк, һәрвакыт, эзлекле рәвештә сүндерү. --- *Туран белән Иран арасында кабынырга торган янгынны һәрчак сүндерә килгән.* Шәһри Казан

**Сүндереп бетерү** Бөтенләй сүндерү. *– Хәзер исә янгыннарны тулысынча сүндереп бетерү түгел, вазгыятьне аз гына яхшырту өчен кеше дә, техника да җитми, – ди ул.* Ватаным Татарстан. *Янып торган учакны даими күзәтергә, ахырдан су яки ком белән яхшылап сүндереп бетерергә кирәк.* Мәдәни җомга

**Сүндереп кую** Сүнгән хәлгә китерү. *Җырлап беткәч кенә, Кәусәрия исенә килде, Таймас көймә моторын сүндереп куйган икән.* З.Мурсиев. *Мин укыйсымны укып, язасымны язып бетердем дә өйдәге барча утларны сүндереп куйдым, тәрәзә пәрдәсен ачып, урамга карадым.* Р.Фәизов

**Сүндереп тору** Сүндергән хәлдә тоту; вакытлыча сүндерү. *Тапшыргычыңны хәзергә сүндереп тор*, *аларда да бардыр ул андый нәрсәләр, синең кайда икәнеңне белеп алмасыннар.* Р.Мөхәммәдиев. *Станокны сүндереп торып, идәнлекләрне әзер такталар өеменә кушып өйделәр.* Д.Булатова

**СҮНЕК** *с.* 1) Сүнгән, янып тормаган

2) *күч.* Нурсыз, дәртсез, рухсыз, боек. *Карчык җыерчыклар белән капланып, кара саргылтланып кипкән йөзе, салынкы кашлар астына әллә кая төпкә, тирәнгә яшеренгән сүнек күзләре белән Булатка күтәрелеп карады ---.* Г.Ибраһимов. *Хатын эре шакмаклы материядән теккән костюм-юбкадан, лаклы туфлидән иде. Какча битле, кәкре борынлы, чырае сүнек һәм киеренке иде.* Х.Камалов

**СҮНҮ** *ф.* 1) Янудан, көйрәүдән, пыскудан туктау. *Борһан, сүнгән тәмәкесен авыз кырыена кыстырган килеш, хисапчы өстәлендәге чут төймәсен шалтшолт салып, үзенең кичә ниләр күргәнен икенче берәүгә сөйли ---.* М.Мәһдиев. *Учак сүнде, калды төтен.* Идел

2) Яктырып торудан туктау. *Мәгарәдә ай яктысы сүнде ---.* Әкият. *Көнбатышта кояшның соңгы кызыл нурлары сүнде ---.* Р.Вәлиев. *Инде ул чак күктә йолдызлар сүнә җем-җелтерәп.* Г.Сөнгати

3) Хәрәкәттән туктау. *Сүнгән вулканнар кратерында урнашкан вулкан күлләре дә очрый (Камчаткада Кроноцкий*

*һәм Курил күлләре).* Башлангыч география курсы. *Тау түбәләре арасыннан сүнмәгән (алар 40 ка якын) һәм сүнгән вулканнар күтәрелеп тора.* Материклар һәм океаннар географиясе

4) Эшләүдән туктау. *Көлтәне кинәт ташласаң, суктыргыч машина тыгыла да, трактор сүнә яки каеш өзелә.* Р.Батулла. *Тик шатлыгы озакка бармады: капкадан чыгып, ике-өч йортны уздымы-юкмы, машина моторы сүнде дә куйды.* Ф.Имамов

5) *күч.* Басылу, бетү, сүрелү. *Өмет сүнде, ышаныч канаты сынды.* Ф.Латыйфи. *Чөнки мәхәббәт сүнде, юкка чыкты, дип уйлады.* М.Яһудин. *Вакыт узган саен, хисләр сүнә ---.* Ф.Яхин

6) *күч.* Төшенкелеккә бирелү; рухсызлану, дәртсезләнү. *Хәлсезләнгән, ялкыны сүнгән тереклек тагы бер кат «Ник?» дип сорарга батырчылык итә алмады.* Ф.Әмирхан. *Мансур да җиңелгәч, малайларның йөзләрендәге көрәш дәрте сүнде.* Г.Әпсәләмов

7) *күч.* Әкренәю, пассивлану, сүлпәнләнү; бетүгә таба бару. *Мәдрәсәдә җәмәгать эшләре сүнгән, «Мәгариф» газетасын чыгару тукталган, гыйльми мәҗлесләр ясау кайгысы беткән иде.* Ә.Фәйзи. *Бераздан этләр өргән, кешеләр сөйләшкән тавышлар бергә буталып, машина гөрелдәве белән бергә ераклашып сүнде.* М.Галиев

**Сүнә бару** Әкренләп сүнү. *Икесе дә Сарай тавы артында сүнә барган шәфәкъ сызыгына карап утырдылар.* М.Галиев. *Аларның сугышчан дәртләре күзгә күренеп сүнә барды.* Т.Нәбиуллин

**Сүнә башлау** Сүнү билгеләре сизелү, күренү. *Күк караңгылыгы әкрен генә эри барып, йолдызлар бер-бер артлы сүнә башладылар.* М.Галәү. *Сугыш беткән елны Зәһриның фани дөньяга дәрте сүнә башлады.* М.Мәһдиев

**Сүнеп бару** *к.* **сүнә башлау**. Акрынлап сүнү. *Яшьлеге сүнеп барган хатыннарның да бит очларына кызыллык йөгерә.* М.Галиев. *Сүнеп барган учакка талгын җил булып исүче, --- язгы кояш нурыдай җылы өстәүче тылсымлы сүз!* Р.Кәрами

**Сүнеп бетү** Бөтенләй, тәмам сүнү. *Ул арада мичтәге ут та сүнеп бетә.* Әкият. *Зур гына урыс авылының кар басып бетергән өйләрендә һәммәсендә дә утлар сүнеп беткән булса да, авылның очындарак бер өйнең тәрәзәсендә ут яктысы ялтырый иде.* Р.Гали

**Сүнеп калу** Ниндидер тәэсирдән соң яки вакыт узгач сүнгән хәлгә килү. *Аның сүнеп калган күзләре кинәт уенчык ат белән уйнап утырган Хафизга төште.* Г.Галиева. *Кызның күңелендәге өмет чаткысы бөтенләй сүнеп калды.* М.Кәбиров

**Сүнеп килү** *к.* **сүнеп бару**. *Сүнеп килгән учак, каен турысындагы ай --- – бөтенесе бер бөтен булып, күздән яшь китерерлек җанлы күренеш мисалында Айдарны тетрәндереп куйды.* М.Галиев. *Дөнья бәясе торырлык шәхеснең гомер шәме сүнеп килә...* Р.Батулла

**Сүнеп тору** Әле, хәзер сүнү; әледәнәле яисә беразга гына сүнү. *Диңгездәге ут төнлә сәгать уникеләрдә генә бераз вакыт сүнеп тора.* Әкият. *Сугышчылар, бирелгән боерык буенча, ракета утлары сүнеп торган арадан файдаланып, куаклыкка таба шуыша башладылар.* М.Яһудин

**СҮРӘ** I *и.* Күбәләрне, вак чүмәләләрне кибәнгә, эскерткә тарттырганда файдаланыла торган җайланма (кисеп алынган башлары тәртә итеп җигелеп, ботак-яфраклары чистартылмаган очлары белән җирдән сөйрәлә торган ике яшь агач). *Сүрә тарттыру. Сүрә чыбыгы. Атны сүрәгә җигү*

**СҮРӘ** II *и. гар.* Коръәндә һәрберсенең үзенә аерым исеме булган һәм һәрберсе аятьләрдән гыйбарәт 114 бүлекнең һәрберсе. *Ул намазны юри озакка сузды, ялыктыргыч озын сүрәләр укыды.* К.Нәҗми. *«Саташа башладым бугай, колагыма әллә нинди серле-сихерле авазлар ишетелә башлады», – дип, җиде мәртәбә тоташтан «Фатиха» сүрәсен укыдым.* Г.Гыйльманов

**СҮРӘН** *с.* **1.** 1) Кызулыгы, эсселеге аз булган. *Урамда көн сүрән, өйдә салкын, җылырак төренеп, сиңа хат язарга утырдым.* Р.Кәрами. *Сүрән кояш карый аланга.* Ф.Шәрипова

2) Көчле түгел, тонык, сүлпән. *Шулай да сүрән ай яктысында мин кәгазьләрнең «хәтәр нәрсәләр» икәнен абайлап өлгердем ---.* Р.Әмирхан. *Чырага эленгән ут сүрән яктылык тарата.* С.Зыялы

3) Чиле-пешле, пешеп җитмәгән; уңмаган (мич ашлары тур.). *Менә, Гөлҗамал абыстай, бу – хәер икмәге; күәс төбен сиңа дип әвәләгән идем, бераз сүрәнрәк булгандыр ахры.* М.Гали

4) *күч.* Әкрен, сүлпән, пассив, эленкесалынкы. *Чынын әйтәм ләкин, Әнвәр иптәш, Сүрән һаман эшнең торышы.* Ш.Мөдәррис

5) *күч.* Күңелсез, кызыксыз; җанлы түгел. *Җылы сүзең белән җылыттың күңелемнең сүрән көннәрен.* Р.Харис. *Билгеле, бу санаулы шатлыклы мизгелләр аның күргән газап-михнәтләре янәшәсендә гаять сүрән тоелалар.* Г.Гайнуллина

6) *күч.* Боек, дәртсез, кәефсезкүңелсез. *Ул Ихтыярның уйга чумган сүрән йөзенә карамыйча, һаман көлүендә булды.* Р.Вәлиев. *Һаҗәрнең агарып калган йөзенә сүрән елмаю йөгерде.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Пассив рәвештә; канәгатьләнерлек дәрәҗәгә җитмичә. *Әмма ашкынып күтәрелергә омтылган солдатның, соңра кече офицерның эшләре, нишләптер, сүрән бара, чөнки артыннан этеп торучысы да, кирәкле акчасы, мөлкәте дә юк.* М.Маликова

**СҮРӘНӘЮ** *ф. к.* **сүрәнләнү**. *Кояш, гүя салкын сыкы белән капланган, сүрәнәеп, урман артына төшеп бара.* М.Галиев. *Талантлы шагыйрьләр, язучылар бүген дә җитәрлек, ә алтмышынчы еллардагы күтәренке иҗат рухы, иҗат халәте, нишләптер, сүрәнәйде.* Р.Вәлиев

**Сүрәнәя бару** *к.* **сүрәнләнә бару**. *Сүрәнәя барган кояш, ак тәлинкә булып, әкрен генә офыкка тәгәри.* М.Галиев. *Җилләр назы кырыслана, кояш нурлары сүрәнәя барды.* М.Кәбиров

**Сүрәнәя башлау** *к.* **сүрәнләнә башлау**

**Сүрәнәя төшү** *к.* **сүрәнләнә төшү**. *Рюмкалар тагын бер кат бушап, җитди дә, мәзәк тә сүзләр булып алгач, мәҗлес сүрәнәя төште.* З.Кадыйрова

**Сүрәнәеп калу** *к.* **сүрәнләнеп калу**. *Шунысы үкенечле: өн дигәнем бер төш кенә имеш. Әллә өнемдә уйланганым*

*төшкә керде, әллә арыган зиһенемне, сүрәнәеп калган күңелемне җылытып җибәрер хыял очкыны микән?* Г.Хөсәенов

**Сүрәнәеп килү** *к.* **сүрәнләнеп килү**

**Сүрәнәеп китү** *к.* **сүрәнләнеп китү**. *Каен утынының кызуы бер-ике сәгать торганнан сүрәнәеп китмәс әле.* Т.Гарипова

**Сүрәнәеп тору** *к.* **сүрәнләнеп тору**

**СҮРӘНЛӘНҮ** *ф.* Сүрәнгә әйләнү. *Абушахман тиз генә җавап бирмәде, йөзе яңадан сүрәнләнде ---.* Г.Әпсәләмов. *Сүрәнләнә кояш, сүрәнләнә, Үзүзенә җәелеп, эреп бара.* М.Әгъләмов. *Көн дә сүрәнләнде.* Р.Батулла

**Сүрәнләнә бару** Аз-азлап, акрынлап сүрәнләнү. *Каршы як стенага төшкән утлы күмер шәүләләре дә, сүрәнләнә барып, юкка чыккан иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Айның сүрәнләнә баруына гаҗәпләнергә һәм юлыннан кире борылырга тиешле Хәлим исә һаман да алга атлавын дәвам иткән иде.* Ф.Яхин

**Сүрәнләнә башлау** Сүрәнләнүе сизелү. *Чәйнеккә кар тутырып кerделәр дә, сүрәнләнә башлаган тимер мич өстенә куеп, учагына утын өстәделәр.* Ф.Яхин

**Сүрәнләнә төшү** Бераз сүрәнләнү; тагын да сүрәнләнү. *Көн кичкә таба сүрәнләнә төшкән.* Н.Хәсәнов. *Оешмадан оешмага атлый-атлый хәле бетте, өмет ялкыны да сүрәнләнә төште.* М.Кәбиров

**Сүрәнләнеп калу** Ниндидер тәэсирдән, күпмедер вакыттан соң сүрәнләнү. *Тик сөйләшү соңында кече лейтенантның йөзе сүрәнләнеп калды: Ваһапов берничә каршы сорау белән аның ялкынына су сипкән кебек итте.* Х.Камалов. *Каршы як стенага мич алдыннан кызыл шәүлә төшкән, ул гөлт итеп бер яктырып китә, бер сүрәнләнеп кала.* Р.Мөхәммәдиев

**Сүрәнләнеп килү** Эзлекле рәвештә сүрәнләнү. *Читтә узган гомеремнең Сүрәнләнеп килә уты.* И.Закиров

**Сүрәнләнеп китү** Көтмәгәндә сүрәнләнү. *Коллега исә, сөйләүләрем барыбер бушка бит дигәндәй, сүрәнләнеп китте.* Ф.Баттал. *Ул Рәфискә күз дә төшерми, дөньядан үткәндәй сүрәнләнеп киткән карашы тәрәзә аша каядыр еракка юнәлгән.* А.Вергазов

**Сүрәнләнеп тору** Әле, хәзер сүрән булып күренү; вакытлыча сүрәнләнү

**СҮРӘНЛЕК** *и.* Сүрән булу хәле. *Сүрәнлекне ничек кичерәсең?* М.Җәлил. *Туган ил сагышы, ата-ананы сагыну хисе, иртәгәге көннең билгесезлегеннән, тормышның авырлыгыннан барлыкка килгән эч пошу, сүрәнлек.* Әдәбият

**СҮРЕЛДЕРҮ** *ф. төш. юн. к.* **сүрелү**. *--- ай да ботаклар әсирлегеннән котылган, йолдызлар чәнечкеле нурларын сүрелдереп, күк иңенә көмешсуефәк яктылыгын сирпеп җибәргән иде.* М.Галиев. *Салкын су хатыннарның да кызуын бераз сүрелдерде, ахры, алар да тынып калдылар.* Ф.Яруллин

**Сүрелдерә төшү** Бераз сүрелдерү. *Бу сүз аның кайнарлыгын сүрелдерә төште.* Н.Фәттах

**СҮРЕЛҮ** *ф.* 1) Уты сүнә бару, кызуы кимү. *Мич сүрелгәнче дип, тизрәк өлгертим дип, бәлеш ясый идем.* М.Гали. *Каен себеркесе белән бетенгәнче чабынмакчы иде дә... мунчасының пары сүрелгән икән шул инде.* Ә.Гаффар

2) Кызулыгы-эсселеге кимү, басылу. *Көн эссесе сүрелгән, биек агач башларына эңгер элена башлаган ---.* М.Маликова. *Җәй челләсе белән сүрелгән.* И.Сабиров

3) Әкренәю, басыла төшү. *Сүрелде җил, тынды бар дөнья.* Ф.Кәрим. *Хәтер дулкыннарын кузгаткан кайнар июль җиле сүрелгән, тынган.* Х.Ширмән

4) *күч.* Әкренәю, сүлпәнләнә төшү, пассивлашу. *Кешеләр Насрыйның сүгенүенә илтифат итмәгән төсле кылансалар да, көлү, кычкыруларның кызулыгы сүрелде.* Ш.Камал. *Мәҗлес инде суына төшкән, кунакларның да кызуы сүрелгән.* Р.Мулланурова

5) *күч.* Кимү, басыла төшү. *Хәзер инде аның шатлыгы да, дәрте дә шактый сүрелде.* Г.Ибраһимов. *Инде бар да онытылды, йөрәктәге сөю уты сүрелде дип йөргәндә, көтелмәгән очрашу Резеданың күңелен кузгатты.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Омтылышлар, теләкләр һ.б.ш.лар юкка чыга башлау, тынычлану, хис-тойгылар басылу. *Бу көлү – картның күңел түрендә күмелеп калган яшьлек дәртенең кинәт кабынып алган чаткысы иде. Әмма ул чаткы бик тиз сүрелде.* М.Галиев. *Кичкә таба әтием сүрелде, әлбәттә, тынычланды.* Р.Вәлиев

**Сүрелә бару** Акрын-акрын сүрелү, торган саен ныграк сүрелү. *Сүрелә барган күмернең алсу-кызыл шәүләсе алыштырган иде аны.* Р.Мөхәммәдиев. *Беренче карашка хәрәкәтчән, сүзчән кебек тоелган Хәмит акрынлап сүрелә барды ---.* Ф.Яхин

**Сүрелә башлау** Сүрелергә тотыну. *Сүрелә башлаган учакны өреп дөрләткәндә, әни кызарган битләренә яргаланган учларын тидергәләп алды.* Ф.Шәфигуллин. *Кызны табу турындагы сүрелә башлаган өмет чаткылары аларның күңелендә яңадан кабынып, дөрләп яна башлаганнар иде.* И.Хуҗин

**Сүрелә тору** Берәр эш-хәл белән бергә сүрелү. *Ул укый тора, халык сүрелә тора.* Ф.Яхин

**Сүрелә төшү** Бераз, берникадәр сүрелү. *Салкынча лапас эченә кергән уңайга шаяртасы килү теләге сүрелә төшеп, әкрен генә сызгырмакчы булды.* Ф.Сафин. *Әмма сабый баланы күргәч, азрак сүрелә төшә һәм --- Нина апаны кабинага төртеп кертә дә кузгалып китә.* Ф.Зариф

**Сүрелеп бару** *к.* **сүрелә башлау**. *Көенечкә каршы, инде кызыксынуыбыз да сүрелеп бара.* Р.Шәрәфиев. *Көзге кояшның тәмам сүрелеп барган чагы.* Ф.Яхин

**Сүрелеп бетү** Бөтенләй сүрелү. *Яшьлектәге кайнар хисләр сүрелеп бетте, әмма таныш түгел кызны онытмады.* М.Кәбиров. *--- Әле исламның сафлыгы сагында торучы көчләрнең рухи куәте сүрелеп бетмәгән.* И.Әмирхан

**Сүрелеп җиту** Тулысынча, ахыргача сүрелү. *Наз-сөюдән сүрелеп җитмәгән килеш, тора-торуга, күлгә төшеп коенып менде.* М.Хәбибуллин. *Сәлимәмне озак вакытлар күрми торудан сагынуым сүрелеп җитмәгән иде.* Ф.Яхин

**Сүрелеп калу** Ниндидер тышкы тәэсирдән соң сүрелү. *Ләкин Вафаны очраткач, аның бу уй-өметләре кинәт сүрелеп калды.* М.Галәү. *Кәефе*

*кисәктән үзгәрүчәнгә әйләнә: ул әле бик тиз кызып китә, әле кинәт боегып, сүрелеп кала.* Р.Гарифуллин

**Сүрелеп килү** Әкренләп, аз-азлап сүрелү. *Көн сүрелеп килә...* Р.Мөхәммәтшин. *Мине дә сук, яшен, янәшәмдәге абый үлде, ничек яшим хәзер дип, күккә карадым, дәһшәтле яңгыр инде сүрелеп килә иде.* Казан утлары

**Сүрелеп китү** Бераз, аз гына сүрелү. *Әмма, килененең бөтен гаме үзләреннән алда барган аттагы Нургалидә икәнен күреп, күңеле сүрелеп китсә дә сиздермәде.* Г.Галиева. *Улы солдат хезмәтен тутырып исән-имин кайтып керү шатлыгы белән балкыган йөзе сүнеп-сүрелеп китте.* И.Нәбиуллина

**Сүрелеп кую** Кинәт кенә сүрелү. *--- шигырь язуга да, әдәбиятка да кинәт кенә күңеле сүрелеп куйды.* Н.Фәттах. *Ләкин шулчак --- бу оекбашны посылка белән үзенә әнкәсе җибәргәнлеген хәтерләп алды, һәм бер мәлгә күңеле сүрелеп куйды.* Ә.Сафиуллин

**Сүрелеп тору** Вакытлыча сүрелгән булу, хәзергә генә сүрелгән булу. *Сүнеп, сүрелеп Тормасын күңел.* Р.Миңнуллин. *Яңгырлар тынды дип, иркенләп сулыш алып, эшкә тотынырга өлгермәделәр, моңарчы сүрелеп торган яу тагын көчәеп китеп, авылга гаскәрләр килеп тулды.* Ф.Сафин

**СҮРЕНКЕ** *с.* Сүрәнләнә төшкән. *Ул күңелле чырай белән килеп керде, әмма боларның сүренке, җитди йөзләрен күргәч, --- йөзендәге яктылык сүнде.* Х.Камалов. *«Шаяртасың» дип тагын бер мәртәбә көлмәкче идем, ләкин хәсрәткә чумган йөзенә, бер ноктага текәлгән сүренке күзләренә карагач, ниятемнән кире кайттым.* Ф.Баттал

**СҮРЕНКЕЛӘНҮ** *ф.* Сүренкегә әйләнү, сүрәнәю. *Һава сүренкеләнү. Күңел сүренкеләнү*

**Сүренкеләнә бару** Акрын-акрын сүрелү, торган саен ныграк сүренкеләнү

**Сүренкеләнә башлау** Сүренкеләнү сизелү

**Сүренкеләнә төшү** Берникадәр, бераз сүренкеләнү

**Сүренкеләнеп китү** Аз гына, бераз сүренкеләнү

**Сүренкеләнеп тору** Вакытлыча сүренкеләнгән булу, хәзергә генә сүренкеләнгән булу

**СҮРЕНКЕЛЕК** *и.* Сүренке булу хәле. *Ах, аз ла яна белүчеләр, ах, сай җанлылар да безне алмаштырачак яшьләр! Йөрәкләренә обывательлек, ниндидер әрсез мещанлык оялаган. Төп мәсьәләләрдә шундый сүренкелекләре «арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит» дигәндәй.* Х.Туфан

**СҮРЕНТЕ** *и.* 1) Тукымадан, нинди дә булса киемнән сүтеп алынган җеп кисәге. *Барысы да уч төбендәге сыман күренә, өстеңдә сүренте дә юк, әйтерсең мине ачыктан-ачык үзеңә чакырасың, тик бер генә адым ясарга кирәк.* Ф.Бүләков

2) Эрләгән кәҗә мамыгына катыла торган киҗе-мамык яки ефәк җеп. *Сүрентесенең төсе мамыгына бер дә туры килмәгән*

**СҮРҮ** *и.* 1) Мендәрнең, ястыктүшәкнең эчке тышлыгы. *Ястык сүрүе ертылган, каз мамыгы бүлмәне тутырган.* Р.Батулла. *Шулай итеп, егерменче гасыр башында Каргалы имамнарының гасырлар буе бөртекләп җыйган абруе сизрәп төшкән мендәр сүрүе кебек сыпыла башлады.* Ф.Сафин

2) *анат.* Организмдагы берәр әгъзаны каплап торган тукыма; элпә, яры. *Әни сүзләренә караганда, сүрүдә --- туганмын ---.* К.Миңлебаев. *СПИД авырыуы вакытында --- иммунитет кими, һәм нинди дә булса кечкенә генә инфекция дә кешедә үпкә, ми сүрүләрен, тирене, ашкайнату органнарын зарарлый.* Минем йорт

3) *физ.* Яры, тышча. *Молекула әйләнеш хәрәкәтендә булганда, электрон сүрүенең әйләнеше әйләнмә ток барлыкка китерә ---.* Фән һәм тел

4) *геол.* Җир шарын әйләндереп алган атмосфера катламы яки аның төше тирәсендәге җир катламнары хасил иткән тышча. *Аерылып чыккан газлар җир гравитациясе нәтиҗәсендә тартылалар һәм алга таба каты сүрү тирәсендә газ катламы рәвешендә акрынлап туплана башлыйлар.* Фән һәм тел. *Планетабызны өйрәнү дәверендә галимнәр аңа хас сүрүләрне, ягъни сфераларны, --- аерып күрсәтәләр: һава сүрүе, ягъни атмосфера; су сүрүе, ягъни гидросфера һәм литосфера – каты сүрү.* Башлангыч география курсы

**СҮРҮЛЕ** *с.* Сүрүе булган. *Үз кроватендагы бер мендәрнең тышын салдыра, кызыл сүрүле мендәргә стакан белән су сибә.* А.Алиш

**СҮРҮЛЕК** *с.* **1.** Сүрү (*1 мәгъ.*) өчен яраклы булган; сүрүгә җитәрлек

**2.** *и. мәгъ.* Сүрү өчен материал. *Кирәкле зурлыкта сүрүлек алып, чиста, коры мамыкны шуның эченә тутырып тегеп куясы һәм тышлыгын гына кигезәсе.* Безнең гәҗит

**СҮС** *и.* **1.** Үсемлек (киндер, җитен һ.б.) сабагын талкып яки башкача эшкәртеп алынган һәм җеп, бау һ.б.ш. әйберләр җитештерү, җылылыкны саклау өчен кулланыла торган чимал. *--- суык керерлек урыннарны Галиулла чүпрәк, сүс тутырып җылытты ---.* З.Зәйнуллин. *Кайгырма, балам, --- эшләр бераз җиңеләйсен, сүс эрләрбез, киндер сугып, үзеңә өр-яңа җылы күлмәк тегеп бирермен.* Д.Каюмова

**2.** *с. мәгъ.* Шул чималдан эшләнгән. *Өстенә алты-җиде кеше атланып утырган, сүс дилбегә белән аякларын боргычлаганнар.* М.Мәһдиев. *Байтирәк --- кәүсә әйләнәли уратып, сүс бауга элмәк ясый башлады.* М.Галиев

**СҮСӘН** *и.* **1.** *бот.* Кыяклылар семьялыгыннан чәчәк төркеме башаксыман булган, соңрак себеркәчкә әйләнгән, культуралы сортлары печәнгә игелә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **тимофеевка**. *Кызым, --- чормадан берәр уч сүсән үләне алып төш әле. Мәтрүшкә бәйләме янында булыр.* М.Хәсәнов. *Күзнең төсе уңса да, без дөньяга, табигатькә авыл малае булып карыйбыз, аныңча гаҗәпләнәбез: «Болын кебек сусыл болытларда сутлы сүсән үсә, нәзек тары...»* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Бик вак һәм йомшак. *Сүсән чәч*

**СҮСӘРТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **сүсәрү**

**СҮСӘРҮ** *ф.* Җеп, йон, мамык очларының сүсләре тырпаеп торырлык хәлгә килеп тузу, кыршылу. *Икенчесе, ныклап эчкә яшерелгәне, – үзләрен бәйләп торган җепләрнең сүсәргәнен*

*сизеп тә шуны танырга теләмәүләреме, туры әйтергә батырчылыклары җитмәүме шунда.* Ә.Хәсәнов. *Шулай булгач, иске йөгән, сусаргән дилбегә белән эшләргә дә риза ул.* Ф.Баттал

**Сусарә бару** Торган саен ныграк сусарү

**Сусарә башлау** Сусарү билгеләре күренү. *Яка төпләре кыршыла башлаган кышкы пальто киеп йөрим мин, шуның өстеннән мамык шәл (сусарә башлаган шәл әле җитмәсә!) бәйләп йөрим.* Гөлшаһидә

**Сусарә төшү** Беркадәр сусарү. *Халатының кабарынкы түш туры аксылланып сусарә төшкән Маһирә Зөбәеровның сузен хупларга ашыкты.* Н.Хәсәнов

**Сусареп бетү** Тәмам сусарү. *Күбесе фронтовиклар, өсләрендә уңып, сусареп беткән солдат киеме.* Г.Галиев

**Сусареп калу** Нинди дә булса хәлдән соң сусарү

**Сусареп киту** Кинәт кенә сусарү

**Сусареп чыгу** Тәмам сусарган хәлгә килү

**СУСЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **суслану**

**СУСЛӘНҮ** *ф.* 1) Сусен алырлык хәлгә килү. *Болынга җитенне сусләнергә тараткannар.* Г.Толымбай

2) Сусарү. *Сусләнгән җиң очы*

**Сусләнә бару** Торган саен ныграк сусләнү

**Сусләнә башлау** Сусләнү билгеләре сизелү

**Сусләнә төшү** Бераз, беркадәр сусләнү

**Сусләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам сусләнү. *Сусләнеп беткән чабата киндерәсе шикелле җеп белән бәйләштерелгән кәрзинкәне аркасына тагып, ашык-пошык пароходка кергәндә, Закир ике төрле бәхетсезлеккә очрады.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Сусләнеп җиту** *к.* **сусләнеп чыгу**

**Сусләнеп калу** Нинди дә булса хәлдән соң сусләнү

**Сусләнеп киту** Кинәт кенә сусләнү

**Сусләнеп чыгу** Тәмам сусләнгән хәлгә килү

**СУСЛӘҮ** *ф.* Ярык, тишек кебекләрне сус белән каплау, томалау. *Ул сапёрлар белән көймәләрне ямый, сусли, чүбекли, сумалалый.* Х.Мөҗәй. *Язга таба көймәләрне кабат сусләп, гудрон белән сылап эшкә әзерләделәр.* И.Салахов

**Сусләп алу** Тиз генә сусләү

**Сусләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча сусләү

**Сусләп карау** Сусләргә тырышу

**Сусләп кую** Алдан ук сусләү, сусләнгән хәлгә китерү

**Сусләп тору** Даими рәвештә яисә әледән-әле сусләү

**Сусләп чыгу** Бар булганны, бөтенесен дә сусләү

**Сусли башлау** Сусләргә тотыну

**Сусли төшү** Бераз сусләү

**СУСЛЕ** *с.* 1) Сус бирә торган, сус әзерләү өчен яраклы. *Муссон яңгырлары башланыр алдыннан, крестьяннар дым ярата торган үсемлекләр – дөге, шикәр камышы, джут (тупас тукымалар, юан баулар эшләүгә тотыла торган сусле үсемлек) утырталар.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) Җепселле, җепселләрдән торган. *Сусле минерал*

3) Арасына сус куелган. *Комплекс эчендә калган йортның сусле бүрәнәләре дә, әти-әнисенең диварлардагы фотосурәтләре дә, иске сәгатьләр дә Илдар әфәнденең студент елларында эшләнгән.* Шәһри Казан

**СУСЧЕЛ** *с. к.* **сусле** (*2 мәгъ.*)

**СҮТЕК** *с.* **1.** 1) Сүтелгән; тукылган, тегелгән, үрелгән җиреннән ычкынган, бушаган. *Әнә тәхетенә сүтек керештән Атылмаган уктай укмаш береккән Хөкемдар да алган ахыр сулышын ---.* Р.Идиятуллин

2) Төзелгән, монтажланган, корылган, җыелган җиреннән таркатылган, таратылган, сүтелгән. *Йортлар сүтек, урам китек, Әрем баскан нигезләр. Булдырырга – хөрәсән-ялкау, Бетерергә – җитезләр.* Х.Вәлиди. *Тәтештә әлегә кадәр 60 данә техника ремонтта тора, Бөгелмәдә – 45, Әгерҗедә исә машина паркының яртысы сүтек.* Татарстан яшьләре

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сүтелгән урын. *Сүтек ертыктан көлгән, ди.* Әйтем. *Кызлар чаршауның сүтекләренә күзләрен генә куеп карап торалар.* М.Фәйзи. *--- сул аяктагы оегымның сүтегеннән ботинкама тыгып куелган иде.* Г.Кутуй

2) Нәрсәдән дә булса сүтеп алынган күн, тукыма һ.б.ш. нәрсә. *Сүтек кисәге*

**СҮТЕЛМӘ** *с. к.* **сүтелмәле**

**СҮТЕЛМӘЛЕ** *с.* Җыеп-сүтеп файдаланыла торган. *Сүтелмәле уенчыклар. Сүтелмәле чыршы. Сүтелмәле биналар*

**СҮТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сүтү**. *Чалмасы сүтелгән, төсләре бозылган иде.* С.Җәлал. *Алар янында урамда машина-трактор. Кайберсе яртылаш сүтелгән.* Р.Кәрами

2) Тегелгән, төйнәлгән, үрелгән һ.б.ш. әйбер таркалу. *Тимер биргән тимер тун – Сүтелгәнче киярмен!* Дастан. *Зилә – утә пөхтә, затлы кеше, минем өчен бөгәрләнгән чалбар, сүтелгән ботинка бавы – гадәти күренеш.* Шәһри Казан

3) *күч.* Гадәти җиреннән чыгу, рәте китү, җае бозылу. *[Байтирәк:] Миртимер, эшләр сүтелде, хәзрәт кайтты.* Т.Гыйззәт. *Безнең зур өметләребез, матур хыялларыбыз тормыш фактына әйләнде дигәндә генә бөтенесе шулай киредән сүтелерме икәнни?* И.Гази

**Сүтелә бару** Торган саен ныграк сүтелү. *Баганага уралган җеп йомгагы сүтелә бара.* Р.Батулла

**Сүтелә башлау** Сүтелергә тотыну. *Бүген бер тишекне ямасалар, иртәгә капчык икенче җиреннән сүтелә башлый.* М.Галәү. *Артык каты режим көтмәгән җирдән сүтелә башлый.* Х.Камалов

**Сүтелә тору** Нәрсә белән дә булса бер үк вакытта, башка бер процесс барышында сүтелү. *Көн артыннан көн үтә, гомер йомгагы һаман сүтелә тора.* И.Гази. *Әйе, гомер йомгагы сүтелә тора.* Р.Кәрами

**Сүтелә төшү** Бераз сүтелү. *Аның кыска калын толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалыйлар ---.* Ә.Еники. *Җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган, кыска толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалаган ---.* Г.Гайнуллина

**Сүтелеп бетү** Тулысынча, тәмам сүтелгән хәлгә килү. *Тагын бер 15–20 елдан иске Казанның күп өлеше сүтелеп*

*бетәр, ахрысы.* Ә.Еники. *Свитерым сүтелеп беткән, --- бары тик бер тар тасма гына калган.* Р.Нуруллин

**Сүтелеп китү** Ниндидер бер моменттан, көтмәгәндә, кинәт сүтелә башлау. *Бәхәссез, бу – күркәм күренеш, әмма бөтенләй үк ачыклык кертеп бетерә алмыйлар һәм моны теләмиләр дә булса кирәк, чөнки гасырлар буена «җырланган» тарихның бөтенләй сүтелеп китүеннән куркалар.* М.Хәбибуллин. *Төн караңгылыгы шул толымнарының сүтелеп китүеннән имеш.* Ф.Яхин

**Сүтелеп тору** Даими яки әледән-әле сүтелү

**Сүтелеп чыгу** Бөтенләй сүтелү

**СҮТҮ** *ф.* 1) Тегелгән, бәйләнгән, үрелгән һ.б.ш. нәрсәне таркату. *Җилбер-җилбер җил үтә, Чәч толымын җил сүтә.* М.Җәлил. *Вакыт-вакыт аның хәтта сикереп торасы, тәбәнәк өстәлне тибеп очырасы, чалмасын сүтеп ыргытасы, ә бу «аңгыра сарыклар»ны выжлатып куып чыгарасы да килеп китә.* Ә.Еники

2) Нинди дә булса техник җайланманы, корылманы детальләп тарату, кисәгеннән кисәккә аеру; *киресе:* **җыю**. *Ашавын-эчүен онытып, шул тегү машинасын сүтеп, яңадан җыйнап, үзенә эш тапкан.* З.Зәйнуллин. *Оганның автоматын сүтеп, биштәренә салып киткәнлеге беленде.* Р.Батулла

**Сүтә бару** Торган саен күбрәк сүтү. *Комсомоллар чалманы сүтә баралар, Сәлим гармунын уйный.* Һ.Такташ. *Айлар үтә, еллар үтә, рәхимсез вакыт кешегә бирелгән гомер йомгагын акрын гына сүтә бара.* Ә.Еники

**Сүтә башлау** Сүтәргә тотыну, сүтәргә керешү. *Эшнең очы-кырые күренгәндәй булгач, бригадир берничә кешегә чатырларны сүтә башларга кушты.* Н.Фәттах. *[Кәримә] кулындагы төргәкләрен сүтә башлады.* Л.Ихсанова

**Сүтә бирү** Сүтүне дәвам итү

**Сүтә тору** Берәр эш-хәлгә кадәр сүтү. *Эшнең җебен акрынлап, очыннан башлап сүтә торуың хәерле шул.* Ф.Яхин

**Сүтә төшү** Беркадәр сүтү; тагы да сүтү

**Сүтеп ату** Кискен хәрәкәтләр белән, тиз-тиз сүтү. *Беләкләре неп-нечкә, бармаклары салам, ә үзе... әйтәм бит, үзе – җебен сүтеп аткан кәтүк!* И.Гази. *Озак та тормый, күрше авыл Әсмабикә түтине бер утыртып урман әйләндерер өчен генә кабызгалый торган машинасын --- бөтенләй сүтеп атты.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Сүтеп бару** Рәттән, эзлекле рәвештә сүтү. *Елларның сер төеннәрен берәмләп сүтеп барам.* Зөлфәт

**Сүтеп бетерү** Тулысынча сүтү. *Коймаларын сүтеп бетергән иделәр.* Ф.Яхин. *Совет чорында төзелгән хастаханәне сүтеп бетерделәр.* Ватаным Татарстан

**Сүтеп җибәрү** Кинәт сүтү, көтмәгәндә сүтү. *Калкулыкка җитүгә, җансакчысы карчыкны ат өстеннән алып аягына бастырды, чүпрәген сүтеп җибәрде.* М.Хәбибуллин. *Гөлкәй, укытучыны үзеннән беркадәр читләштереп, урындыкка куйган төргәген алды, сүтеп җибәрде.* Х.Ширмән

**Сүтеп карау** Сынау максаты белән сүтү. *Чалбарның җөен сүтеп карасалар, шаккаттылар: анда Максимның әлеге югалган уймагы кереп калган иде.* М.Галәү

**Сүтеп кую** Тиз арада яки алдан сүтү. *Әни аңа: «Син нишлисең, абзый?!» – дип кычкыруына каршы, ул: «Чыгыгыз өйдән, миңа өегезне сүтеп куярга куштылар», – дип җавап кайтарды.* М.Әмир. *15×20 метрлы чатырларны намаз укыр алдыннан гына корып, намаз тәмамлангач сүтеп куярга да мөмкин булачак.* Ватаным Татарстан

**Сүтеп ташлау** *к.* **сүтеп ату**. *Аннан соң фельдшер бармактагы марляны сүтеп ташлады.* Ш.Камал. *Ул мылтыкны ялт кына сүтеп ташлый, безнең күз алдында ялт кына җыя.* Ә.Маликов. *Менә шундыйларның ишеген шакып, күп һөнәр иясе Анатолий кайсының да булса пианиносын сәгать урынына сүтеп ташлый да аннары инде майлап-җайлап ремонтлый.* Р.Низами

**Сүтеп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле сүтү; хәзерге моментта сүтү белән мәшгуль булу

**СФЕ́РА** *и. гр.* 1) Шар яки аның эчке өслеге (Җир шары, аның тирәсендәге һава киңлеге тур.). *Җир сферасы. Һава сферасы*

2) *мат.* Барлык нокталары үзәктән тигез ераклыкта булган йомык өслек; шарның тышкы өсйөзе. *Сфераның мәйданын исәпләү*

3) *кит.* Нәрсәнең дә булса таралу-урнашу чикләре, тәэсир-хәрәкәт итү өлкәсе. *Җирнең тарту көче сферасы. Халыкара йогынты сфералары өчен көрәш*

4) Тармак, юнәлеш, өлкә. *Житештерү сферасы. Хезмәт күрсәтү сферасындагы житешсезлекләр*

5) Рухи эшчәнлек һ.б.ш. нәрсәләр өлкәсе; даирә. *Кызыксыну сферасы. Хисләр сферасы*

**СФЕ́РИК** *с.* 1) Сфера (*1 мәгъ.*) формасындагы, шар формасында булган. *Гөмбәзнең ян-ягы яссы, сферик яки цилиндрик булырга мөмкин.* Төзү материаллары. *Сферик өсйөз. Сферик пыяла*

2) *мат.* Сфера (*1 мәгъ.*) эчендә яки сферик өсйөз өстендә урнашкан. *Сферик сектор. Сферик өчпочмак*

3) *мат.* Сферага (*1 мәгъ.*) караган, шуңа мөнәсәбәтле; шундый җисемнәрне, формаларны тикшерә торган. *Татарча чыганакларда без аерым күк җисемнәренә һәм яктырткычларга кагылышлы атама һәм терминнарны гына түгел, бәлки сферик тригонометриягә, астрономик хисаплауларга кагылышлы терминнарны да очратабыз.* А.Тимергалин. *Ноктаның сферик координатлары*

**СФИНКС** *и. гр.* 1) Борынгы Мисырда фиргавеннең дәрәҗәсе, куәте, әһәмияте символы буларак куелган, ятып торган кеше башлы арыслан кыяфәтендәге таш сын; әбелһәүл. *Бу шигырь – сфинкс турында, пирамидалар янына яткан таш арысланнар турындагы шигырьдән бер кыйтга, ләкин таш арысланнар турында гына яздымы икән бөек шагыйребез Роберт Әхмәтҗан.* Р.Батулла. *Карнак белән Луксор гыйбадәтханәсе арасында борын заманда сфинкслар аллеясы булган. Анда биш йөз сфинкс тезелеп торган.* Казан утлары

2) Борынгы грек мифологиясендә: арыслан аяклы, елан койрыклы, канатлы хатын-кыз (яки хатын-кыз башлы

канатлы арыслан) кыяфәтендәге зат. *Берничә мең еллык тарихы булган пирамидалар, Сфинкс, мумияләр арасында йөрү хисләрне кузгаткан иде: юлда беркем дә сөйләшмәде, һәркем чүлгә таба күзләрен текәп уйланып кайтты.* М.Мәһдиев. *Соңгы куплетына кадәр Мисырдагы пирамидалар янында сакта торучы Сфинкс турында сүз бара дип ышанып укыйсың.* М.Юныс

3) *зоол.* Павианнар ыругыннан тарборынлы маймыллар төре

4) *зоол.* Балкараклар семьялыгыннан зур күбәләк төре

5) *зоол.* Йонсыз мәчеләрнең бер токымы. *Процедураны сфинкс хуҗасы видеога һәм фотога төшерергә дә кыенсынмаган, аларны интернетта тараткан.* К.Солтанова. *Моның өчен [тату ясату] ул сфинкс токымлы йонсыз мәчене анестезия ярдәмендә бер сәгатькә йоклаткан.* Шәһри Казан

**СХЕ́МА** *и. гр.* 1) Берәр җайланма, прибор һ.б.ш.ларны тәшкил иткән, үзара бәйле аерым өлешләр тупланмасы; шуларның эш принцибын чагылдырган сызым. *Күп кенә фермаларда үрдәк бәпкәләре өчен автоэчергечләр куелган икән. Аларны безнең фермаларда да җайлаштырырга мөмкин булачак. Миндә моның өчен әзер схема бар.* М.Максуд

2) Нәрсәнең дә булса төзелешен, урнашу тәртибен гадиләштереп кенә күрсәткән график рәсем; план. *Шигырьдәге сүз басымын билгеләгәч, аның үлчәмен схема рәвешендә язып чыгарга кирәк.* Г.Нуриев. *Беренче алты строфаның алтысы «бу, бу, –, бу» схемасы белән килә дә, җиденчесендә алмашлык сигез мәртәбә кабатлана.* С.Исмәгыйлева

3) Берәр нәрсәне эшләү, башкару тәртибе, тормышка ашыру планы

4) Нәрсәнең дә булса кыска гына гомуми тасвирламасы, аңлатмасы. *Пьесаның схемасы. Докладның схемасы*

5) *күч.* Бик тапталган форма, әзер план; артык коры, җансыз тасвирлама. *Һәммәсен дә гади схема буенча гына аңлатып булмый.* Ф.Галимуллин

**СХЕ́МАЛАШТЫРУ** *ф. кит.* Гомуми төстә генә тасвирлап, гадиләштереп бирү. *Мәҗит Гафуриның бу әсәрдә биргән эшче сурәте – гомумиләштереп, схемалаштырып бирелгән сурәт.* Г.Нигъмәти. *Мәсьәләне [әдәби үсешне] артык гадиләштерү, схемалаштыру гына булыр иде бу.* Г.Халит

**Схемалаштыра бару** Акрынлап схемалаштыру

**Схемалаштыра төшү** Бераз гына схемалаштыру

**Схемалаштырып бетерү** Артык схемалаштыру

**СХЕМАТИЗМ** *и. рус к.* **схемачыллык**. *Әмма бирердә дә азмы-күпме схематизм күрергә мөмкин.* И.Нуруллин. *Әдәби әсәрләрдә схематизм чире булганны белгән кебек, әдәби тәнкыйтьнең дә кайвакыт шундый чиргә дучар булуын онытырга ярамый безгә.* Г.Ахунов

**СХЕМА́ТИК** *с. кит.* 1) Схема (*1 мәгъ.*) рәвешендә бирелгән, схема рәвешендә күрсәтелгән. *Анда [I тасвирда], мәсәлән, язылачак әсәр бүлекләренең схематик бүленеше (44–46 нчы кәгазьләр), Тукайны белүчеләрнең адреслары (182 нче кәгазь) --- һәм башкалар бар (219–221 нче кәгазьләр).* З.Шәйхелисламов

2) *күч.* Гомуми сызыклар белән генә, гадиләштерелеп бирелгән. *Әсәрдә гражданнар сугышы елларында Әюп хәзрәт образындагы дин әһелләре алып барган эшчәнлек дөрес яктыртылса да, Сафа картның тиз генә аңы үзгәреп, революция ягына авышуы схематик рәвеш ала.* З.Шәйхелисламов. *Автор тормыш вакыйгаларын сурәтләгәндә схематик, шаблон алымнардан нык сакланып эш итә һәм дөрес эшли.* Г.Иделле

**СХЕ́МАЧЫЛ** *с.* **1.** *к.* **схематик**

**2.** *рәв. мәгъ.* Гомумиләштереп, гадиләштереп; схема рәвешендә. *Гади бер итекченең иске карашларыннан арынып, эшчеләр хәрәкәтенә кушылу темасын Ә.Фәйзи сыйнфый көрәш ягына авышып, схемачыл эшли.* З.Шәйхелисламов

**СХЕ́МАЧЫЛЛЫК** *и. кит.* Сурәтләүнең, тасвирлауның гомуми сызыклар белән генә гадиләштереп бирелү күренеше. *«Безнең көннәр» каһарманнарын шушы таләпләрдән килеп тикшерү әсәрдәге характерларның схемачыллыктан азат булганлыгын күрсәтәчәк.* Г.Нигъмәти

**СХОД** *и. рус* 1) *тар.* Авыл халкының мир җыены. *1897–1898 елларда Җилем-Каран авылында, уразада көндез ашаган һәм урамда гармун уйнап йөргән өчен, солдатка каралачак яшьләрне сходка чакырып кыйныйлар.* С.Кудаш

2) Авыл хезмәтчәннәренең гомуми җыелышы; җыен

**СХО́ДКА** *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә эшчеләрнең, студентларның һ.б.ш. революцион рухтагы җыелышы. *Көрәшче шагыйрьнең котылгысыз һәлакәткә якынлашканда алдан күреп язган әлеге юллары (1912) революцион студентлар сходкасында катнашкан В.Ульяновның хөкем карарыдай яңгырый торган сүзләрен хәтердә яңарта.* З.Мансуров

**СХОЛАСТ** *и. рус кит.* 1) Схоластика (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Романның эчтәлеге болай: улы Гаргантюаны тәрбияләү өчен, король һәммә нәрсәне ятларга мәҗбүр итүче схоласт галимнәрне чакыра.* Педагогика тарихы

2) *күч.* Формаль рәвештә, гамәлгә нигезләнмичә генә фикер йөртүче; формалист. *Татар руханилары да бер яктан царизмга, икенче яктан милли буржуага хезмәт итеп, һәртөрле яңа фикерләргә каршы рәхимсез каты көрәш алып бара һәм, Көнчыгыш мистик идеологияне сакларга тырышып, мәктәп-мәдрәсәләрдә схоластикага гына урын биреп, һәртөрле кечкенә реформаларга да каршы чыга.* Г.Кашшаф. *Хәмидинең эшче Гафур белән бәхәсе, Хәйдәр Сыртлановның озын нотыгы, җәдитчеләр белән схоласт динчеләр бәхәсе шактый озакка сузылганнан соң, сүз Тукай тирәсенә әйләнеп кайта.* З.Шәйхелисламов

**СХОЛА́СТИКА** *и. лат.* 1) Урта гасырлар философиясендә хакимлек иткән, ясалма, формаль логик дәлилләр ярдәмендә дин догмаларын теоретик яктан аңлатуны максат итеп куйган юнәлеш. *Схоластика тарафдары*

2) Абстракт, формаль фикер йөртүләргә генә нигезләнгән, тәҗрибәне исәпкә алмаган һәм тормыштан аерылган тәгълимат; буш, мәгънәсез бәлем. *Әлбәттә, ислах кирәк, әлбәттә, Урта гасыр схоластикасы арбасына*

*утырып, без халкыбызны тәрәккый иттерә алмаячакбыз.* А.Расих. *Бүгенге көндә ул схоластика белән имгәтелеп, илаһи гыйлем һәм дөньяви белем чыганагы булудан туктаган.* И.Әмирханов

**СЦЕНА́РИЙ** *и. ит.* 1) Сәхнәдә куеласы вакыйгаларның кыскача эчтәлеге һәм анда катнашучылар исемлеге. *[Клара]: Сценарий расланган, фамилияләр хәл ителгән!* И.Юзеев. *Кече күләмле әсәрләр, театраль миниатюралардан торган сценарий яздым.* Р.Батулла

2) Сәхнәләштерү, берәр тамаша оештыру яки фильм төшерү өчен, берәр әдәби әсәр нигезендә эшләнгән яки махсус язылган әдәби әсәр. *Кинофильм нигездә әдәби әсәр – сценарийга корылган, ә кинода яңгыраган музыканың бурычы – әдәби эчтәлекне эмоциональ көчәйтү.* Җ.Фәйзи

3) Гомумән, берәр чараны үткәрүнең планы, схемасы

4) Вакыйгаларның барышында ихтимал вариантларның берсе. *Эшнең нинди сценарий белән китәсе билгеле түгел бит*

**СЦЕНА́РИЙЧЫ** *и.* Кинофильм, тамаша, тапшыру һ.б.ш.ның сценарий авторы

**СЦЕНА́РИУС** *и. лат.* Актёрларның сәхнәгә чыгу тәртибен күзәтүче, спектакльне алып баручы режиссёр ярдәмчесе

**СЦЕНО́ГРАФ** *и. гр. махс.* Театр рәссамы, сценография белгече

**СЦЕНОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* 1) Театр сәхнәсен сәнгатьчә бизәү, матурлау сәнгате

2) Шундый бизәү, матурлау күренеше үзе

**СЧЁТ** *и. рус* 1) *фин.* Товар яки башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен акча түләү документы, түләнәсе сумманы күрсәткән рәсми кәгазь, язу. *[Фазылҗан абзый:] Тик минә промкомбинаттан счёт яздырып алырга гына өлгерә алмадым.* Р.Төхфәтуллин. *Анда доверенностьлар, счётлар белән инде Нәркис көтеп тора иде.* М.Мәһдиев

2) Банк, кредит оешмасы һ.б.ш.лар аша финанс операцияләре үткәрү хокукы; шул хокукны раслый торган документ. *Кичә чит илдәге счётларны ябуның соңгы көне иде.* Шәһри Казан

3) Исәп-хисап эшләрендә куллану өчен, дүртпочмаклы кысага рәт-рәт шуып йөри торган түгәрәк төймәләр тезелгән әсбаб; чут. *Колхоз канцеляриясендәге хисапчыларның счёт төймәләре, колхозчыларның хезмәт көннәрен санап, өзлексез шалт-шолт килеп торды.* М.Әмир. *[Хуҗаның бите] Симезлеге тәмле ашавыннан булса, кызарып-кучкылланып торуы, конторда счёт төймәсе тартып кына ятмыйча, вакыты килеп җитүгә, чалгысын күтәреп, әрәмәгә яки басуга чыгуыннандыр, мөгаен.* Ш.Рәкыйпов

◊ **Счёт салу** *к.* **чут салу**. *Ишектән кергәч тә уң яктагы өстәлдә счёт салып утыручы яшь кеше алдына килеп басты Батыр. Счёт салучының бераз бушаганрак минутын көтеп, эндәшми торды.* М.Әмир

**СЧЁТ-ФАКТУ́РА** *и. рус икът.* 1) Сатыла торган товарның хакын, санын, күләмен күрсәтеп, сатып алучыга җибәрелә торган исәп-хисап язуы, документы

2) Коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен квартир хуҗасына җибәрелә торган исәп-хисап язуы

**СЧЁТЧИК** *и. рус махс.* Санап, исәбен алып бара торган аппарат; санагыч. *Сигезенче март көнне минем хатынга үз укучылары унике чиләк су сыешлы агач кисмәкләргә утыртылган ике пальма гөле, бер җәйге зонтик, электр счётчигы, үзбәк чәйнеге --- бүләк иткәннәр.* Г.Мөхәммәтшин

◊ **Счётчикка кую** Берәр төрле бурычы булган кешегә янап, бурычын билгеле вакытка кайтаруны таләп итү, көчләп кайтарту. **Счётчикка утырту** *к.* **счётчикка кую**. *[Беренче кеше:] Агачлар әзер булырга тиеш. Әгәр әзер булмаса, сине счётчикка утыртабыз! Монысының нәрсә икәнен үзең дә беләсеңдер.* Ә.Гаязов

**СЪЕЗД** *и. рус* Сәяси партия яисә милли, профессиональ һ.б. оешмаларның, аерым халык төркемнәре вәкилләренең иҗтимагый-сәяси җыелышы; корылтай. *Волостной земский съездга төрле авыллардан делегатлар җыела.* М.Әмир. *Күптән түгел мин аны Татарстан язучылары съездында очраттым.* И.Низамов

**СЪЁМКА** *и. рус махс.* Махсус аппарат ярдәмендә видео, фото һ.б.ш. ларга теркәү процессы. *Алар үзләре белән бер вагон төрле кирәкле нәрсәләр алалар: көрәкләр, палаткалар, чүкечләр ---, кыр аптечкасы, геофизик съёмкалар өчен төрле катлаулы приборлар...* Дөньяда ниләр бар

**СЫБАЙ** *и. фар.* **1.** Атлы гаскәри, җайдак. *Оясы якын булганга, күрәсең, бу өч сыбайны моннан үткәрәсе килми иде кошның.* Т.Нәбиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Атка атланган, атлы. *Берәр сәгать көткәннән соң, өч сыбай кеше килеп, аларның берсе мине үзенең артына менгәштереп, теге якка (елганың аръягына) алып чыкты.* М.Гафури

**СЫБЫЗГЫ** *и.* 1) Эченнән һава өреп үткәргәндә сызгыру тавышы чыгара торган корал, җайланма. *Якында гына милиция сыбызгылары чиный башлагач: – Булмый... Калдыр мине, браток. Үзеңә авырлык алма. Йөгер... Алар мине ауларга чыккан, – диде.* З.Фәтхетдинов. *Искәндәр, милиция сыбызгысы чырылдавына сискәнеп, уянып киткәндәй булды.* Р.Вәлиев

2) Шундый коралдан чыккан сызгыру тавышы. *Беренче сыбызгыдан соң ук йөгереп китү. Сыбызгы ишетелү*

3) *муз.* Берәр хайван яки кош сурәтендә ясалган, сызгыру өчен тишекләре булган уенчык. *Бүре белән төлке кыздан үзләре шүрләгәннәр. Чөнки аның кулында бабасы ясап биргән сыбызгы булган.* Р.Хафизова

4) *күч.* Бик чәрелдәп, артык күп сөйләшүчән, сер тота белмәгән кеше. *Хәер, шулай булмый хәле дә юк: ничек алар «фәлән егеткә», «фәлән кызга» дип, шул тикле зур серне минем күк бер сыбызгы малайга әйтеп торсыннар? Бөтен авылга таралсын дипме?..* Ш.Маннур

◊ **Сыбызгы борын** 1) Борын аша сулаганда сызгырган тавышлар чыгаручы (гадәттә балалар тур.). *Мөршидә: Әлли, бәлли, сыбызгы борын!* К.Тинчурин. *Шапырай карт таный алмаслык булып үзгәргән иде. Чыбыркысын асып,*

*киез эшләпәсен күзенә кадәр батырып киеп: – Һәй-й, мөртәтләр!.. Сыбызгы борыннар! Кая керәсез? – дип, сыерларны тирги-тирги торып киткән иде.* М.Хәсәнов; 2) «Борын астын сөртерлек тә үсмәгән әле, сер тота белми» дигән мәгънәдә малай-шалайга карата кимсетеп әйтү сүзе. *Бу сыбызгы борыннар янында юл кешесенә барыбер тынгы булмас.* В.Имамов. **Сыбызгы тоттыру** Алдау. **Сыбызгысына бию** Бүтән кеше сүзе белән гамәл кылу; кураена бию

**СЫБЫЗГЫ́ КУАГЫ** *и. бот. диал. к.* **сәрви**

**СЫБЫЗГЫЛЫ** *с.* 1) Сыбызгысы булган. *Сыбызгылы бала, уйный-уйный, тотучыдан качып йөри.* К.Закирова. *Гөнаһ шомлыгына каршы, сыбызгылы милиционер килеп җитә.* Т.Галиуллин

2) Сызгыра торган. *Малайның бәләкәйдән калган сыбызгылы чебеше бар иде.* Ә.Баян

**СЫБЫЗГЫЧЫ** *и. сир.* Сыбызгы (*1 мәгъ.*) сызгыртучы. *Егет, сыбызгычыга ияреп, балалайка зеңләтүчегә карап җырлап җибәрде ---.* М.Хәбибуллин

**СЫ́ВОРОТКА** *и. рус мед.* Каннан, кан сүленнән әзерләнә, дәвалау һәм диагностика өчен файдаланыла торган кайбер даруларның исеме. *Дифтериягә каршы сыворотка уколын ясагач, аны йогышлы авырулар шифаханәсенә алып китәргә кирәк.* Г.Мөхәммәдева. *Вакциналар һәм сывороткалар әзерләү*

**СЫГУ** I *ф.* 1) Эчендәге яки составындагы суны, сыек матдәне кысып чыгару, суын алу. *Тормадагы әче тәмне бетерү өчен, кишер белән катнаштыру алдыннан, суын сыгып алырга киңәш ителә.* Йорт эшләре. *Йөзем сыгу*

2) Юган, юешләнгән әйберне борып, кысып, сеңгән суын чыгару, агызу. *Әдилә тиз генә коену костюмын салып сыгып киде, шулай ук тиз генә күлмәген киеп алды да таллыктан чыкты.* М.Хәбибуллин. *Ул хатын-кызлар шикелле озак ышкып, күбекләндереп уа да борып сыга.* М.Юныс

3) *күч.* Берәр нәрсәдән мөмкин булганча күп, калдырмаслык итеп алу, файдалану. *Җирне ничек яратырга, җирдән ничек байлык сыгарга – аннан, Терентий Семёновичтан, күп нәрсәгә өйрәнергә була...* Р.Төхфәтуллин. *Ә кукуруз, үзең беләсең, туфракны сыгып ала белә.* М.Хәбибуллин

4) *күч.* Бик аз булган нәрсәне тартып-сузып булдырырга, җыярга тырышу. *Кулга килеп кергән хәзинәнең ычкыну ихтималыннан курыккан Идият никадәр юмаламасын, никадәр тасма телләнмәсен, кыздан фельетонлык материал сыгып чыгара алмады.* И.Нуруллин. *Минем урында Америка тикшерүчесе булса, лайдетекторын, ягъни ялганны ачыклау приборын тоташтырыр иде дә һәртөрле юллар белән үзе теләгән күрсәтмәләрне сыгып чыгарырга тырышыр иде.* М.Насыйбуллин

5) *күч.* Әһәмияткә ия булмаган, кирәксез урыннарын төшереп калдырып, кыскартып, кирәген генә алу. *Мемуарларны сыгып бастырып чыгару*

**Сыга бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә сыгу

**Сыга башлау** Сыгырга тотыну

**Сыга бирү** Бернигә карамыйча сыгу эшен дәвам итү. *[Самавырны] Сыга бирәсең – «көмеш бүксә» әкренләп бушый бара, аның саен, гәүдәңә никадәр сеңдерсәң дә, күкрәкләрең киңәеп, җаныңа җиңеллек һәм хозурлык күбрәк иңгәндәй тоела бара.* Э.Касыймов. *Ул, эчтән көлә-көлә, безнең күңелләрдәге әремне сыга бирде, сыга бирде, бугазга әче су төйнәлде. Без ачы тавыш белән: «Ялган!» – диеп кычкырдык.* Р.Зәйдулла

**Сыга тору** Даими, эзлекле рәвештә сыгу; хәзергә сыгу

**Сыга төшү** Тагы да ныграк сыгу; бераз сыгу

**Сыгып алу** Беркадәр, кыска вакыт эчендә, тиз генә сыгу. *Тиз генә төшеп, киемнәремне сыгып алдым.* М.Әмир. *Алар кыска вакыт эчендә хакимияттән мөмкин булганның барын да сыгып алырга омтылалар.* Р.Хәкимов

**Сыгып бетерү** Ахырына кадәр, сыеклыгы беткәнче сыгу. *Бакалары сөрәеп утырып калганчы, бөтен суын сыгып бетерәбез.* Г.Якупова

**Сыгып кую** Тиз арада яки алдан сыккан хәлгә китерү

**Сыгып тору** Һәрвакыт, даими, регуляр рәвештә сыгу

**Сыгып яту** *сөйл. к.* **сыгып тору**

**СЫГУ** II *ф.* 1) Элекке торышына кире кайта торган, сыгылмалы нәрсәләрне бөгү, ию, кәкрәйтү. *Алар шаяралар, җил агачларның барлык урыннарын капшый, башта бер яктан исеп ботакларын сыга, яфракларын шыбыр-шыбыр аралый, аларның аскы аксыл яклары күренеп күтәрелә.* Ф.Садриев

2) *күч.* Зәгыйфьләндерү, көчсезләндерү, кысу, җәберләү, изү. *Революциягә хәтле ул кызыл мал белән нык кына сәүдә итсә дә, революция еллары аны сыктылар, ул сумасызланды.* Г.Толымбай. *Хәтта күпне күргән «диңгез бүреләре» дә мондый сугышка күнегә алмыйлар, һөҗүмнең каян китереп сугасын белмәү, аны каршы алырга әзер булмау аларны эчтән ашый, сыга иде.* И.Низамов

◊ **Сыгып ташланган лимон кебек** Хәлсез, арып беткән яки рухы төшкән кеше турында

**Сыга бару** Торган саен ныграк сыгу

**Сыга башлау** Сыгарга тотыну. *Авыр, киеренке эш, тузан-туфрак һәм черки – барысы бергә җыелып, Вәгыйзьне бөгә, сыга башлады шикелле тоелды.* Н.Фәттах

**Сыга бирү** Бернигә карамый, сыгу эшен дәвам итү

**Сыга төшү** Бераз сыгу; тагын да ныграк сыгу

**Сыгып алу** Тиз генә сыгу

**Сыгып тору** Әледән-әле сыгу, хәзер, сөйләү моментында сыгу

**СЫГЫЛДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сыгылу** II. Сыгылмалы нәрсәләрне бөгү, ию, кәкрәйтү. *Агач ботакларын сыгылдыру*

**СЫГЫЛМА** *с.* **1.** 1) *к.* **сыгылмалы**. *Чәчүчеләрнең җыйнак, сыгылма буынлысы, муены, кулы сеңерләнеп торганы: – Суң? – дип сорады.* Ә.Гаффар. *Аның сыгылма гәүдәсе әле йомарлана, әле туп кебек очып китә.* М.Хәсәнов. *Үгездәй таза ике эсэсчы, җиңнәрен сызганып, кулларына озын сыгылма чыбыклар тотып, комендантның боерыгын көтәләр.* Г.Әпсәләмов

2) Хәрәкәтчән, үзгәрүчән, пластикалы. *Аның тавышы җиңел, сыгылма, хәрәкәтчән булырга тиеш.* Р.Заһидуллина

**2.** *и. мәгъ.* Сыгылу хәрәкәте. *Бию сыгылмалары*

**СЫГЫЛМАЛЫ** *с.* 1) Элекке торышына кабат кайта торган, бөгелүчән, сыгылучан, сомгыл. *Шул мәлне, катер юлга чыгарга торганда, яр буена чаптар атта теге ханым килеп чыкты һәм сыгылмалы такта траптан кызу-кызу атлап менгән шәпкә кычкырып җибәрде ---.* С.Сабиров. *Атлас, хуҗаларча хәрәкәт белән тумбочка тартмасын ачып, сыгылмалы ак пластинкалар тартып чыгарды да радиоланы тоташтырды.* М.Маликова

2) Нәфис, зифа һәм җиңел хәрәкәтле. *Аның күлмәге дә ефәк түгел, ә бәлки гәүдәсе буйлап аккан су агымы гына булып күренә, сыгылмалы тәненең һәр хәрәкәте күзне алырга ирек бирми, ымсындыра, мавыктыра, үз янына чакыра иде.* М.Маликова. *Алга сылу кызлар йөгереп чыкты, аларның сыгылмалы гәүдәләре тоташтан чин ефәгенә төрелгән кебек --- иде.* Р.Зәйдулла

3) Җиңел һәм сыгылучан; җиңел гәүдәле, җитез хәрәкәтле. *Сыгылмалы егет*

4) *күч.* Төрле шартларга, очракларга җайлашырга мөмкинлек бирә торган. *Сыгылмалы чаралар. Сыгылмалы алымнар*

5) *күч.* Кешеләргә, төрле шартларга ияләшә, җайлаша белә торган. *Кеше акылының сыгылмалы булуы*

**СЫГЫЛМАЛЫЛЫК** *и.* 1) Сыгылмалы булу үзлеге, эластиклык; сыгылучанлык, бөгелүчәнлек. *Актёр сөйли белү, тавыш, сүзләрне ачык итеп әйтә белү (дикция), гәүдә белән ритмик хәрәкәтләр ясау сәләте, сыгылмалылык (пластика) кебек тышкы тәэсир итү чараларының барысын да тирән һәм бик яхшы итеп үзләштереп, барысын да үзендә булдырырга тиеш.* И.Илялова. *Сәнгать осталарының бөтен бер буыны гасырдан-гасырга әнә шулай Мисырның схематик рельеф һәм статуяларыннан, шартлы, богаудагы, чикле, үзгәрешсез фигураларыннан, хәрәкәтсезлектән һәм бертөрлелектән кеше гәүдәсенең хәрәкәтен, сыгылмалылыгын, көчен күрсәтүгә таба барды.* Матурлык нәрсәдә?

2) Кешенең характеры турында: сыгылучанлык, зирәклек, сизгерлек. *Эләктерүен эләктерде Фәһимә, ләкин сыгылмалылык дигәнең җитәкче кешенең яртылаш алга, яртылаш артка чигенүенә әйләнгәч, башбаштаклыкка юл ачыла...* Ф.Садриев

**СЫГЫЛУ** I *ф. төш. юн. к.* **сыгу** I. *Ичмасам, ике күзенең берсеннән дә сыгылып сыңар яшь тамчысы да чыкмый иде.* Ф.Садриев. *Шулвакыт Шәүкәтнең күзеннән ике эре бөртек – борчак хәтле күз яше сыгылып чыкты.* Я.Зәнкиев

**СЫГЫЛУ** II *ф. төш. юн.* 1) Элекке торышына кире кайта торган сыгылмалы, эластик әйберләргә карата: бөгелү; батынкылану. *Баулардан тартып, чананы елга аркылы өстери башлагач, боз сыгылды, әмма ярылмады.* Н.Ихсанов. *Бигрәк тә сул як стена буендагы ике такта көянтә кебек сыгылып төшкән.* М.Әмир

2) Иелү, бөгелү. *Малай эчкәрәк узды, аска йомшак яфраклар түшәлгән, эчендә кипкән үләннәр сыгылып өелгән иде.* Я.Зәнкиев. *Аеруча Дүчән басуында арыш башаклары авырлыктан җиргә кадәр сыгылып төшкән була.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Авырлыкларга, кыенлыкларга чыдый алмыйча бирешү, сыну. *Кайгыдан сыгылып төшмичә, гәүдәсен туры тоткан хәлдә, Баязитның йомык күзләренә, аксыл сары кәгазь төсле чыраена карап барды ул.* Ш.Маннур. *Равилнең иң зур егетлеге шунда: кыен чакта, авыр чакта ул сыгылып төшми, киресенчә, сугыш китергән авырлык һәм кыенлыкларны җиңә-җиңә, шактый иркә һәм йомшак табигатьле сыек малайдан ир-егеткә, шинельсез солдатка әйләнә бара.* В.Нуруллин. *Ә Бикташ сынмаган иде, сыгылмаган иде. Бу исә егет булып җитлегүнең беренче билгесе иде.* М.Маликова

◊ **Сыгылып төшү** Авырлыкларга, җәберләүгә, кайгыга бик нык бирешү. *Әни, эшләмичә, тәмле ашарга яратса, әтием, сыгылып төшеп, борыны белән җир сөрә.* Э.Шәрифуллина

**Сыгыла бару** Торган саен ныграк сыгылу

**Сыгыла башлау** Сыгылуга таба йөз тоту; сыгылырга тотыну

**Сыгыла төшү** Тагы да ныграк сыгылу; бераз сыгылу

**Сыгылып бетү** Бөтенләй, тәмам яки барысы да сыгылу

**Сыгылып калу** Берәр хәлдән соң сыгылган хәлгә килү. *Ул кыр буйлап киткән вакытта, арыш биленә кадәр сыгылып кала.* Дөньяда ниләр бар

**Сыгылып китү** Кинәт сыгылу

**Сыгылып тору** Берникадәр вакыт сыгылган хәлдә булу, бөгелеп тору; сыгылу үзлегенә ия булу. *Боз, тиз генә бирешергә теләмәгәндәй, бераз вакыт шатырдап, сыгылып торды да, ат авырлыгын күтәрә алмыйча, тагын уелды.* М.Әмир

**СЫГЫЛУЧАН** *с.* Сыгылмалы, бөгелүчән, эластик. *Шуннан соң бөҗәкләр бөгелүчән һәм сыгылучан булалар.* Ә.Халидов

**СЫГЫЛУЧАНЛЫК** *и.* Сыгылмалылык, сыгылучан булу үзлеге

**СЫГЫЛЫШ** *и.* 1) Сыгылмалы булу дәрәҗәсе. *Буеның сыгылышын тикшерү*

2) Салыныш. *Такта сыгылышы*

3) *күч.* Тапкырлык, зирәклек. *Дипломатик сыгылышлар*

**СЫГЫМЧА** *и. сир. к.* **сыгынты**

**СЫГЫНДЫРУ** *ф. иск. к.* Сыендыру. *Баланы үзеңә сыгындыру*

**СЫГЫНТЫ** *и.* Берәр азыкны сыгу юлы белән әзерләнә торган эчемлек, сыек ашамлык. *Тутык таплары беленер-беленмәс кенә булганда аларны лимон сыгынтысы белән бетерергә мөмкин; моның өчен тап тигән урынны берничә мәртәбә лимон сыгынтысы белән чылатырга да бу урынны кайнар үтүк яки чәйнек өстенә куеп бераз киптерергә, аннан соң юарга кирәк.* Йорт эшләре

**СЫГЫНУ** *ф. иск. к.* **сыену**. *Аларның бу шаулашуында, бер яктан, Тәзкирәгә карата ачу булса, икенче яктан, яңа бригадирга сыгыну, аннан ярдәм көтү, аңа ышаныч баглау ишетелде.* Н.Фәттах. *Әнием биш вакыт намазын калдырмыйча Аллага сыгына да бит...* Э.Шәрифуллина

**СЫГЫТ** *и.* 1) Мәетне күмгәндә елап-сыктап башкарыла торган йола җыры, матәм җыры

2) *әд.* Йола поэзиясенең борынгы жанры: җеназа, шулай ук туй, аерылып китү йолалары белән бәйле лирик-драматик җыр. *Сөембикә сыктавы*

**СЫГЫТЧЫ** *и.* Мәрхүм өчен такмаклап-такмаклап елаучы, сыктап күз яше түгүче, матәм җыры башкаручы; наихә

**СЫДЫРГЫЧ** *и. диал.* Агачтан кабыкны алу өчен кулланылган махсус корал, инструмент

**СЫДЫРТУ** *ф.* 1) Ышкытып тырнату, каезлау, җиңелчә суйдыру. *Ул да булмады, текә биеклектән төшкәндә, тигезлеген югалтып, җирне капларга өлгермәгән юка карны авыр гәүдәсе белән сыдыртып, иңкүлеккә тәгәрәп китте.* А.Вергазов

2) Бик тиз атлап яки йөгереп бару. *Олыгайган тәрәзәдән карыйм: офык аръягында дегетле әремнән сыдыртып, җигүле ат артыннан яланаяклы дәрт чаба...* М.Галиев

3) *күч.* Тиз генә юкка чыгу, чыгып китү; нәрсәдәндер котылу, качу

**Сыдыртып алу** Аз гына сыдырту

**Сыдыртып бетерү** Бөтенләй, тулаем сыдырткан хәлгә китерү

**Сыдыртып җибәрү** Кинәттән кенә сыдырту

**СЫДЫРУ** *ф.* 1) Нык ышку, каезлау, тырнау нәтиҗәсендә эз калдыру; сыдырту. *Яким Зиновьевичның муенын пуля да сыдырып киткән.* Х.Камалов

2) Бер тирәдә, бер җирдә урнашкан әйберләрне ике бармак арасына яки учка кысып үткәреп чистарту, аралау (мәс., каурыйны йоннан, яшь чыбыкны, үлән сабакларын бөреләрдән, яфраклардан һ.б.), шул рәвешле җыю, төшерү, сыпырып алу. *Яфрак зурлыгындагы җиләкләрне сыдырып кына аласың да ярты сәгатьтә чиләкне тутырасың да куясың...* Г.Гыйльманов

3) Җиңне, балакны югары таба тартып менгерү яки бөкли-бөкли сызгану. *Бәхтияров, җиңен сыдырып, сул кулын Әхәтовка таба сузды.* М.Насыйбуллин. *Ногманов, җиңен сыдырып, йонлач беләгенә таккан алтын сәгатенә күз төшереп алды.* Д.Гайнетдинова

4) Нәрсәне дә булса урыныннан тартып, шудырып кую. *Фатыйма алай да, тәрәзә пәрдәсен сыдырып, ишегалдына күз салды.* М.Хәбибуллин

5) *күч.* Эшне өлгерлек белән, җитез башкару, бөтенләй эшләп бетереп бару. *Өй эшен сыдырып эшләүче килен. Эшне ул сыдыра гына!*

6) *күч.* Рәттән, тоташ барын да ашау; тиз-тиз генә ашап кую

7) *күч.* Чыбык, камчы кебек озынча сыгылмалы әйбер белән сугу, суктыру. *[Атны] Чыбыркы белән сыдырсалар, омтылып бер-ике атлый да тагы туктый.* М.Әмир. – *Ачуланырга... син бит минем хатыным түгел, – диде дә Нәдерша, әйбәт кенә атлаган атына камчысы белән сыдырып, алга ыргып китте.* И.Туктар. *Зәкәрия чыбыркысы белән сыдырып, суккалап, үгезнең койрыгын борып та карый: тегесе яткан җиреннән кыймылдамый да.* Ф.Абдуллин

8) *күч.* Гомумән, сугу. *Берне сыдырам хәзер, кит!*

**Сыдыра бару** Рәттән сыдыру, булган берсен сыдыру

**Сыдырып алу** Бераз, тиз генә, бер мәртәбә сыдыру. *Менә аларның берсе, кранның түрдәге чан янына шуышканын күреп, ашыкмыйча гына шунда таба китте, чан эчендәге сыеклык өстенә утырган элпәне таяк белән сыдырып алып, кырыйдагы савытка ташлады.* М.Маликова

**Сыдырып ату** Тиз генә, ачу белән, кисәк сыдыру. *[Кемдер] Бөтен куркуларны онытып, бар гәүдәсен, башынкүзен томалаган шул юрганны сыдырып атып, аягүрә басарга, кулларыңны өскә сузып, шул якты һәм көчле күзләргә таба үзеңә барырга куша төсле.* Ш.Маннур

**Сыдырып бетерү** Барысын да, бөтен җирен, күп итеп сыдыру. *Төннеңтөн буена каты ятагының бер ягыннан икенчесенә ташлана, башын бәреп, кулларын сыдырып бетерә, яткан җирендә бөтерелә, бәргәләнә, тешләрен кыса, иреннәрен чәйнәп бетерә.* Җ.Рәхимов

**Сыдырып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә сыдыру

**Сыдырып карау** Сынау максаты белән сыдыру. *Бер атна тоташ утыруда чиле-пешле ун йомырка сыдырып карадым, корсак үсми генә, малайлар.* М.Хәбибуллин

**Сыдырып кую** Бер тапкыр яки кинәт сыдыру

**Сыдырып тору** Һәрвакыт, әледәнәле сыдыру яки сөйләү моментында сыдыру эше белән мәшгуль булу. *Таяк белән теләсә кемне мулла итәргә була дип уйлаганга күрә, дәрес вакытында аның тал чыбыгы бертуктаусыз чыжылдап, әле беребезнең, әле икенчебезнең аркасын сыдырып тора иде.* Н.Сәфәрев

**Сыдырып узу** Узышлый сыдыру. *Абдулла аны күкрәгенә алып, төймәләреннән җиңел генә бер сыдырып узды да күңеленә килгән беренче көйне уйнап җырлый башлады.* Э.Касыймов

**Сыдырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да сыдыру

**СЫДЫРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сыдыру** *(1, 3, 7 мәгъ.). Өр-яңа йөгән каешы мине күтәреп утырткан көчле кулларда сыдырылып калды, ә мин чак-чак кына атның ялына тотынып өлгердем.* Г.Гыйльманов

2) Нык ышкылып тырналу, суелу, кырылу, эз калдыру. *Аның сыдырылган чыраена, дерелдәп торган кулларына карап, Луиза шаркылдап көлеп җибәрде.* Р.Зәйдулла. *Насихның бите сыдырылып канап чыкты.* Р.Хафизова. *Стенага кулы бәрелеп, тиресе сыдырылды, ул моңа игътибар итмәде.* М.Насыйбуллин

3) Балак яки җиңнең җыерылып күтәрелүе; оекның шуып төшүе. *Аның изүләре ачылган, бер җиңе сыдырылып төшкән иде.* Н.Дәүли

**Сыдырыла бару** Тоташ, рәттән сыдырылу

**Сыдырылып алу** Бераз сыдырылу

**Сыдырылып бетү** Тәмам, бик нык сыдырылу. *Тик анда-санда гына биек ярга бөрешеп ышыкланган, кабыклары сыдырылып беткән гарип тал ояалары һәм тубылгы куаклары гына күренгәли.* И.Салахов. *Ә күктә күз чагылдырырлык кояш, эссе. Ләкин ул Оренбург даласында түгел, сыдырылып беткән, тырпаешып торган агачлы Волхов урманында.* Ә.Давыдов

**Сыдырылып китү** Көтмәгәндә сыдырылу. *Ләкин иң гаҗәбе шул иде: Габделбәрнең суыкта кызарган йөзе бик ямьсез булып җәрәхәтләнгән: уң күз төбендә йодрык кадәр фонарь күгәреп*

*тора, борыны ямьшәеп шешеп чыккан, уяк тирәсе дә сыдырылып киткән...* Э.Касыймов

**Сыдырылып тору** Даими яки регуляр рәвештә сыдырылу

**Сыдырылып чыгу** Бөтенләй, тулаем сыдырылу

**СЫЕГАЙТУ** *ф.* Сыеклау, сыекландыру. *Ванга кырыклап инеш коя, ләкин алар күл суын төчеләндерә дә, хәтта сыегайта да алмыйлар.* А.Муранов

**СЫЕГАЙТЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **сыегайту**. *Сыегайтылган спирт эремәсеннән тыш, инглиз тозы кристалларын акрынлап өстәү дә яхшы анестезияли.* Ә.Халидов. *Бәхетсезлек очракларын булдырмас өчен, бакыр һәм көмеш ацетиленидларын тәҗрибәдән соң сыегайтылган хлорид кислотасы белән таркаталар һәм әзерләнгән савытка салалар.* Органик химия

**СЫЕГАЮ** *ф.* 1) Сыек (*1, 2 мәгъ.*) хәлгә килү. *Эремә сыегаю. Кан сыегаю*

2) Куелыгы, тыгызлыгы кимү, сирәкләнү. *Көн җылынган саен, ул [кар] сыегая-сыегая килә.* Г.Исхакый. *Бары тик икенче көнне генә, кояш чыгып, көнне каршы алгач, елга буендагы томан сыегаеп юкка чыккач кына, ике як та орышка әзерләнә башлады.* М.Хәбибуллин

3) Төсләр, караңгылык һ.б.ш. турында: тоныклану, төссезләнү, кимү. *Ахырда бу кызыллык, сыегаеп, чуар бер шәүләгә әйләнә, һәм поезд кире артка таба чапкан шикелле була.* Ә.Еники. *Кояш диңгез артына батты. Диңгез култыгы өстендәге аллык, сыегаеп җәелә торгач, бөтенләй сүнде.* И.Туктар

4) *куч.* Азык, акча һ.б.ш. азаю, җитми башлау, муллыгы кимү. *Акча ягы сыегайды*

5) *куч.* Азаю, сирәкләнү, кимү. *Бер уйлаганда, гел онытылган хәлләр дә бит, юк шул, картайган, көчгайрәте сыегайган саен, Гайзулланың вөҗданын һаман нидер әзәрлекли, нидер кимерә.* М.Хәбибуллин

6) *куч.* Таләпләргә туры килми башлау, тиешле дәрәҗәдә булмау. *Репертуар сыегаю. Акыл сыегаю*

**Сыегая бару** Торган саен ныграк сыегаю

**Сыегая башлау** Сыегаюга таба үзгәрү

**Сыегая төшү** Бераз сыегаю; тагын да сыегаю. *Тайга эчендәге төнге куе караңгылык бераз сыегая төшкәч, отряд урыныннан кузгалды.* И.Туктар

**Сыегаеп бару** Торган саен ныграк сыегаю

**Сыегаеп бетү** Тәмам сыегайган хәлгә килү

**Сыегаеп калу** Берәр хәлдән соң сыегайган хәлгә килү

**Сыегаеп килү** Соңгы арада сыегаюы арту; күптәннән сыегаю

**Сыегаеп китү** Артык сыегаю, кинәт сыегаю

**Сыегаеп тору** Һәрвакыт сыегайган хәлдә булу

**СЫЕК** *с.* **1.** 1) Сыеклык хәлендәге; агучан, агу үзлегенә ия булган. *Бу басым кимегән урыннарда гына кызган тау токымнары эриләр. Кайнар һәм сыек масса – магма хасил була.* Галәм. Җир. Кеше. *Бер-берсендә эри, ләкин төрле температурада кайный торган сыек матдәләр катнашмасын, өлешләп куу ярдәмендә, аны тәшкил итүче состав өлешләренә аерырга мөмкин.* Органик химия

2) Куе түгел, куелыгы тиешенчә булмаган, суы кирәгеннән артык булган. *Беркөнне Пушкин чатындагы Профсоюз йорты ашханәсенә көнгә бер тапкыр талон белән ашарга баргач, минем тәлинкә төбендәге сыек карабодай боткасын ялмап кына йотканымны күргән бер агай, кызганып, миңа берьюлы ике талон сузды...* Х.Сарьян. *Сыек азык өләшү өчен көйләнгән андый таратучылар бик уңайлы һәм яхшы эшли.* Татарстанда терлекчелек

3) Сирәк, тыгыз түгел (томан, болыт, пар кебекләр тур.). *Җәйнең теләсә кайсы вакытында моржаларның берничәсеннән булса да сыек төтен күтәрелә, тизәк янган әчкелтем ис сизелә, берән-сәрән калган этләр өрүе ишетелә.* Җ.Рәхимов

4) Тоныкъ, кучкыл, караңгы, якты булмаган (яктылык, тон һ.б.ш. тур.). *Урман эчендә ялгыз торган йортның тәрәзәләреннән сыек кына ут яктылыгы күренде.* С.Рафиков. *Рәмилә --- зур, якты тәрәзәле үз бинасына таба юнәлде һәм, кышның сыек караңгысында, биш катлы йорт артына борылып, күздән дә югалды...* Э.Касыймов

5) Төс атамалары алдында килеп, аларның гадәттәгедән чагыштырмача тоныкъ, җетелеге, куелыгы кимрәк булуын белдерә. *Ярый әле маникюры сыек алсу, куе кызыл булса, сөртеп ташларга туры килә иде.* С.Сөләйманова. *Чыннан да, Сөембикә манарасы ике катлы, сыек яшел төскә буялган, тәрәзәләре гөмбәзле.* Р.Кәрами. *Үзәнлеккә төшеп, сыек зәңгәр төтен күтәрелгән, машиналар туктаган, халык мәш килеп ял иткән урынга таба атлады, күкрәген киереп, тирән итеп сулады.* Ф.Садриев

6) Сирәк үскән, куе, еш булмаган. *Лагерная станциясе ягыннан, сыек яфраклы зелпе агачлары арасыннан, җиргә сырышып, сикерергә җыенган ерткыч адымы белән үрмәләп килүче стражниклар күренде.* К.Нәҗми. *Мулла, сыек тал чыбыкларын куллары белән аралап, юлга бакты – дүрт-биш дистә чамасы җайдак ашыга-кабалана Уфага таба узып бара иде.* Җ.Рәхимов

7) Ныгымаган, ныклыгы, катылыгы җитәрлек дәрәҗәдә булмаган. *Агачтан юнып, я сыек талдан яки яшь юкә кабыгыннан үреп, төрле нәрсәләр ясый белүче һөнәрле малайлар бар иде.* М.Әмир. *Шуның өчен ул кулына сыек тал чыбыгы белән пәке алып утырды, бөтен дөньясын онытып таяк сырлый, янәсе.* Л.Ихсанова

8) *куч.* Зәгыйфь чыга торган, көчсез (аваз тур.). *Әниләренә охшатып каңгылдарга тырышкан бәбиләрнең тавышлары сыек иде әле, шулай да барысы бергә гөлдердәгәч, шактый гайрәтле чыкты.* И.Низамов

9) *куч.* Аз, җитешсез яки тулы түгел. *Сыек алкышлар. Сыек сый* // Ким, тулы, камил түгел. *Тик арада хәбәрсезләр, сыек акыллылар да бар икән, алары инде аптырабрак калды.* Ф.Яхин. *Медицина өлкәсенә сыек белем белән эләгермен димә.* Ватаным Татарстан

10) *куч.* Хәлсез, көчсез, зәгыйфь (мускул, гәүдә һ.б.ш. тур.). *Ул – карап торуга ярыйсы ук озын буйлы егет, тик буыны сыек икән. Ярты юлда гөр-*

*селдәп ауды.* Ф.Яруллин. *Аның сыек гәүдәсе ике якка дугаланып киткән аяклар өстендә чак-чак тора сыман.* М.Мәһдиев

11) *күч.* Кыенлыкларга, авырлыкларга тиз бирешүчән; йомшак холыклы, ихтыярсыз, булдыксыз. *Равилнең иң зур егетлеге шунда: кыен чакта, авыр чакта ул сыгылып төшми, киресенчә, сугыш китергән авырлык һәм кыенлыкларны җиңә-җиңә, шактый иркә һәм йомшак табигатьле сыек малайдан иргеткә – «шинельсез» солдатка әйләнә бара.* В.Нуруллин

12) *күч.* Эчтәлеге буш, кыйммәте булмаган, түбән сыйфатлы, әһәмиятсез. *Сыек эчтәлекле әсәр. Сыек доклад*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Куе итмичә, куертмыйча; тыгызламыйча. *Камыр сыек булган*

2) Тонык, төссез, сүрән генә. *Буяулары сыек чыга*

3) *күч.* Эчтәлеге тулы түгел. *Батулла, кичә программасы бик сыек күренә, азак өчен, бер-бер гадәттән тыш нәрсә эшләргә кирәк иде бит.* Р.Батулла

**СЫЕКЛАГЫЧ** *и. махс.* **1.** Сыек итә торган матдә. *Сыеклагыч сыйфатында еш кына су пары кулланыла, ул конденсация вакытында реакция продукларыннан җиңел аерыла.* Нефть продуктлары пиролизы

**2.** *с. мәгъ.* Сыекландыра, сыегайта торган. *Эч сыеклагыч дару. Кислород сыеклагыч препарат*

**СЫЕКЛАНДЫРУ** *ф. к.* **сыеклау**. *Аның әһәмияте шунда: озон Җир өстенә Кояштан килә торган ультрафиолет нурларны сыекландыру бурычын үтәп килә.* Философия

**Сыекландыра бару** Акрынлап, торган саен ныграк сыекландыру

**Сыекландыра төшү** Беркадәр сыекландыру

**Сыекландырып бетерү** Тәмам, ахырга кадәр сыекландырган хәлгә китерү

**Сыекландырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәгә китереп сыекландыру

**Сыекландырып кую** Алдан сыекландырган хәлгә китереп әзерләү

**Сыекландырып тору** Даими яки регуляр рәвештә сыекландыру

**СЫЕКЛАНУ** *ф.* 1) Сыек (*1, 2 мәгъ.*) хәлгә килү. *Кәҗә дә – әби берлән бабайны ун ел ашаткан, ун ел аларга кәҗә тәкәләре, кәҗә бәрәннәре үстергән кәҗә дә үзгәрде: аның да сөте азайды, сыекланды.* Г.Исхакый

2) Сирәкләнү; куелыгы, тыгызлыгы кимү. *Томан шактый сыеклана төшкән, ул эри, танклар күз алдымнан югала.* Г.Госман

3) Җетелеге кимү, тоныклану, төссезләнә төшү; яктылыгы кимү. *Шушы ерып чыкмаслык уйларга чумып утырган арада, җәйге кыска төн, тәмам сыекланып, таң яктылыгында эри дә башлады.* М.Юныс

4) Сыгылучан, эластик, пеше хәлгә килү. *Парда тоткан чыбык сыеклана*

5) *күч.* Көчсезләнү, хәлсезләнү (тән әгъзалары тур.). *Бусыннан соң, сизәм, аяклар үзләреннән-үзләре сыекланып талгынга күчте.* З.Фәйзи

6) *күч.* Кимү, азаю (акыл, эш һ.б.ш. тур.)

**Сыеклана бару** Торган саен, азазлап ныграк сыеклану

**Сыеклана башлау** Сыеклануга таба үзгәрү. *Менә шушындыйрак чакларда, яшерен чир төсле, яңадан бәреп чыга инде ул. Бигрәк тә Бикбулат шикелле акылы сыеклана башлаган борынгы картларда.* Г.Бәширов

**Сыеклана бирү** Бернигә дә карамый сыеклануын дәвам итү

**Сыеклана тору** Вакыт үткән саен сыеклану

**Сыеклана төшү** Бераз сыеклану. *Киеренкелек менә аз булса да кимеде төсле бит. Һәрхәлдә, чырайларда шом сыеклана төште.* Ә.Баян

**Сыекланып алу** Беразга гына, тиз генә, кыска вакыт эчендә сыеклану

**Сыекланып бетү** Бөтенләй, тәмам сыекланган хәлгә килү. *Эх, бу башны, эчә-эчә миләре сыекланып беткән шул, ни генә бирә алыр икән бу чибәр ханымга?* З.Кадыйрова

**Сыекланып җитү** Тиешле дәрәҗәдә сыеклану

**Сыекланып калу** Берәр хәлдән соң сыекланган хәлгә килү. *Күзләрендәге элекке җете зәңгәрлек сыекланып калды.* Н.Хәсәнов

**Сыекланып килү** Соңгы вакыт аралыгында гына сыеклану. *Әле төн караңгысы сыекланып кына килә иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Сыекланып китү** Көтмәгәндә ниндидер сәбәптән сыеклану. *Моңарчы нык торган саннары йомшап, буыннары сыекланып киткәндәй булды.* З.Фәйзуллин

**Сыекланып кую** Кисәк сыеклану

**Сыекланып тору** Хәзер сыекланган хәлдә булу

**СЫЕКЛАТКЫЧ** *с.* **1.** *к.* **сыеклагыч**

**2.** *и. мәгъ. к.* **сыеклагыч**. *МТБ (махсус тикшерү бүлмәләре) идәннәре тигез, таймый торган, чистарту өчен уңайлы һәм кислота, селте, сыеклаткыч һәм башка химик матдәләр тәэсиренә чыдамлы материалдан эшләнә.* Хезмәт иминлеге

**СЫЕКЛАТУ** *ф.* 1) *к.* **сыеклау**. *Катыкны сыеклатып, әйрән ясау*

2) Сирәкләтү; куелыгын, тыгызлыгын киметү

**Сыеклата бару** Тоташтан, рәттән сыеклату

**Сыеклата төшү** Бераз сыеклату

**Сыеклатып бетерү** Тәмам сыекланган хәлгә китерү

**Сыеклатып җибәрү** Аз гына сыеклау, сыекланган хәлгә китерү

**Сыеклатып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә сыеклату

**Сыеклатып тору** Даими, регуляр яки хәзер сыеклату. *Тышта әле артык караңгы түгел; шәфәкъ кызыллыгы караңгылыкны азрак сыеклатып тора...* Ш.Камал

**СЫЕКЛА́У** *ф.* 1) Сыек әйбер кушып сыегайту; сыеклык хәленә китерү. *Татарларда тәлинкә эченә спираль рәвешендә түгәрәкләп дога сүзләре язу, шул язуны суда сыеклап эчү гадәте бар.* Н.Фәттах

2) Ят нәрсәләр кушып, нәрсәнеңдер сыйфатын төшерү. *Кешегә үз канындагы табигый нәрсәләр генә җитми, ул аны төрле агулы матдәләр белән сыеклап маташа, әллә нинди тәэсирләр эзли.* Ш.Галиев

**Сыеклап алу** Тиз арада, бераз сыеклау

**Сыеклап бетерү** Бөтенләй сыек хәлгә китерү

**Сыеклап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә сыеклау

**Сыеклап тору** Даими рәвештә сыеклау

**Сыеклый бару** Торган саен ныграк сыеклау

**Сыеклый башлау** Сыекларга тотыну

**Сыеклый төшү** Бераз сыеклау; тагын сыеклау

**СЫЕКЛЫК** *и.* 1) Агып китә, күләмен үзгәртмичә, салынган савыт формасына керә торган матдә; сыекча. *Куеныннан уймак хәтле савыт чыгарып, мичкәдән аңа сыеклыкны тамызды.* Р.Сәгъди. *Сыеклык салынган пробирканы җылытканда, аның авызы үзегездән һәм янәшәдә эшләүче иптәшләрегездән читкә юнәлтелгән булырга тиеш.* Органик химия

2) Сыек булу хәле, рәвеше. *Турысызыклылык, коры агитация, образчагыштыру чараларының сыеклыгы ярылып ята.* М.Җәлил. *Шулай да бер күңелсезлек була язды: конвоирлар конфискацияләнүче мөлкәтнең сыеклыгыннан шикләнделәр.* Ш.Алпар. *Буяуның сыеклык дәрәҗәсен билгеләү*

**СЫЕКЧА** *и.* Сыеклык, су сыман сыек матдә. *Грек табибы яраны ниндидер сыекча белән юды, шул сыекчага манып, чиста чүпрәк каплады, ханга шул ук сыекчаны ике сәгать саен эчәргә бирде.* М.Хәбибуллин. *Карап торышка гел харап була инде: пыяла савыт эчендә, үрле-кырлы сикереп, ачык шәмәхә төстәге сыекча кайный!* М.Маликова

**СЫЕКЧАЛЫ** *с.* Сыекча салынган, эчендә сыекчасы булган. *Бүген без ул кадәр курыкмыйбыз: таң алдыннан майор Ильин безгә күп итеп гранаталар һәм яндыргыч сыекчалы шешәләр китертеп өлгерде.* И.Гази

**СЫЕМ** *и.* Сыйдырышлылык. *Үпкәнең сыемы*

**СЫЕМЛЫ** *с.* 1) Билгеле сыйдырыштагы. *Аз сыемлы савыт*

2) Сыйдырышлы булган, күп сыешлы, зур

**СЫЕМЛЫК** *и.* Сыйдырышлылык

**СЫЕНДЫРУ** *ф. йокл. юн. к.* **сыену**. *Алай да гаиләсенә сыендырган малайны: Яхъя кышны аларда чыккан.* Җ.Рәхимов. *Уяу булыгыз, Зәйтүнә Мәҗитовна, ирегезне ул еланның сихереннән коткарыгыз! Ә сез беркатлылыгыгыз белән һаман аны үз яныгызга сыендырасыз.* М.Маликова. *[Илдус:] Бу йорт кайчандыр сине дә, мине дә сыендырды.* З.Кадыйрова

**Сыендыра бирү** Бернәрсәгә карамастан сыендыру

**Сыендыра килү** Электән үк, эзлекле рәвештә сыендыру

**Сыендырып тору** Даими, регуляр яки хәзер сыендыру; вакытлыча сыендыру

**СЫЕНУ** *ф.* 1) Иркәләнү өчен яки берәр кешедән яклау эзләп, берәү янына сырышу, елышу, кочагына керү. *Зәйтүнә елмаеп аңа сыенды, һичбер сүз дәшмичә күзләрен йомды.* Ш.Маннур. *Лариса, аның күкрәгенә сыенып, куллары белән баш артын сыйпады.* М.Маликова

2) Посу, ышыклану, яшеренү, качу. *Ул, капканы ачып, кача-поса гына ишегалдына керде һәм, тагы кемнәндер яшеренеп, өй стенасына сыенды.* А.Расих. *Ни хикмәт, явыз этләр дә тына, кар аларның йон араларына тулып ак төскә мана, алар да, авыр койрыкларын селкетергә тырышып, ышыкка – тоткыннар арасына сыеналар һәм әкрен генә шыңшыйлар.* А.Гыйләҗев. *Моннан исә яткыл гына урында талтирәкләр арасына сыенган бәләкәй генә авыл күренеп тора иде.* Җ.Рәхимов

3) Иминлекне саклардай җиргә, ярдәм күрсәтерлек кеше янына урнашу. *Инде бел, әй егет, без – Бәрмәкиләр булабыз, син безгә сыену урыны эзләп килгәнсең икән, безгә синең эшләреңне тәмам җиренә җиткерергә тиешле булды.* Мәҗмугыл-хикәят

4) Башлыча сәяси сәбәпләр аркасында, үз иленнән качып, башка илгә китү. *Милли хәрәкәт әгъзасы хәзер Австриядә сыенган*

5) *күч.* Алладан ярдәм сорау яки өмет итү. *Ә ышану – бер үк вакытта Аллага сыену һәм Алладан курку да ул...* Ә.Еники. *Максуди иҗатында кайгыхәсрәт авазлары, Аллага сыену мотивлары көчле бирелгән.* С.Алишев. *Кем дә кем Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә сыена икән – максатын тапмый калмас, чөнки Аның юмартлыгы чиксез, нигъмәте сансыз.* Мәҗмугыл-хикәят

◊ **Сыеныр урын тапмау** Өе, тору урыны булмау. *Моны үз басмалары юкка чыккач, сыенырга урын тапмау нәтиҗәсе, бичарадан ни чара бер нәрсә, дип әйтә алмыйбыз.* М.Гайнетдинов. **Сыеныр урыны булмау** *к.* **сыеныр урын тапмау**. *Әти-әнисе исән-сау булса, --- кайтып китәр иде, башка сыеныр урыны юк шул.* Т.Галиуллин

**Сыена төшү** Бераз сыену. *Рәмилә абыйсына сыена төште һәм туганнарча якынлык белән йомшак кына итереп кителдәп алды ---.* Э.Касыймов

**Сыенып кую** Тик торган җирдән, кисәк кенә сыену. *Шул чак, кинәт сискәнеп китеп, Рухия Равилгә тагын да ныграк сыенып куя һәм уттай кайнар куллары белән аның кулын кысып ала.* В.Нуруллин

**Сыенып тору** Хәзер сыену; гел сыенган хәлдә булу. *Мадам кабер өстендәге таш келәмгә яңагын куеп, сыенып торды бераз.* Р.Мөхәммәдиев

**Сыенып утыру** Сыенган хәлдә булу. *Утәдем фермасы үр кашына ук сыенып утырган, шул сәбәпле моннан совхозның байтак җирләре уч төбендәге шикелле күренә иде.* Э.Касыймов. *Шул кече авылларның бигрәк тә берсе, тау-калкулыклар арасына сыенып утырганы – миңа, артыгракт ыр – Сәлимәмә ошады.* Ф.Яхин

**СЫЕНЫЧ** *и.* Сыенырга мөмкин булган урын, җир яки кеше. *Көбә күлмәк өсләремдә, Билемдә – булат кылыч. Явыз Иван этләреннән Монда соңгы сыеныч...* М.Сафин

**СЫЕНЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **сыену**. *Әнкә белән килен зур кайгының шәфкатьсез авырлыгы астында, ана белән бала кебек, бер-берсенә сыенышып елаша башладылар.* Г.Бәширов. *Серле бүләкне телевизор янына урнаштыргач, күршедән кассета алып керделәр, аннары, бер-берсенә сыенышып утырып, телевизор экранына төбәлделәр.* Г.Гыйльманов

**СЫЕР** *и.* 1) Кайбер куштояклы мөгезле эре хайванның тешесе. *Болан сыеры. Поши сыеры*

2) Сөт өчен асрала торган йорт хайваны. *Ул ак киемле, фәрештәдәй кызлар сыер савучылар икән.* С.Рафиков. *Авыл урамыннан көтү кайта, җиленнәре тулып торган сыерлардан сөт исе килә.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Үз гомерендә сыер савучы булып эшләгән әнисенең бармак буыннары бүртеп-бүртеп тора.* М.Хәбибуллин

3) *астр.* Борынгы Көнчыгыш йолдызнамәсендә алтмыш еллык календарь циклының 12 төрле хайван белән билгеләнгән икенче билгесе; шул билгегә туры килгән ел; шул елда туган кеше. *Сыер елы суык була.* Х.Мәхмүтов

4) *күч.* Авыр гәүдәле, акрын кыймылдаучан, тупас хәрәкәтле кеше. *Ай, аягыма бастың бит, сыер!*

◊ **Сыер дагалап йөрү** *к.* **сыерга камыт кидерү**. **Сыер ялаган** Бернәрсә дә калмаган. *Ул да түгел, контора ягыннан өстенә френч кигән, симез гәүдәле, ярты башын сыер ялаган бер агай килеп чыкты.* З.Фәтхетдинов. **Сыер ялап алгандай** Моменталь, бик тиз арада. *Әле генә аны шашындырган сүз өянәге сыер ялап алгандай юкка чыкты.* З.Фәхретдинов. **Сыерга камыт кидерү** Кирәкмәгән, файдасы булмаган, мәгънәсез эш белән шөгыльләнү. **Сыерның сөте телендә булу** «Сөтнең күп һәм яхшы сыйфатлы булуы сыерны ашатуга бәйле» дигән мәгънәдә

**СЫЕРКОЙРЫК** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан озын туры сабаклы, сары чәчәкле, яфраклары төксел икеellлык үләнчел үсемлек; *русчасы:* **коровяк мучнистый**

**СЫЕ́Р ТЕЛЕ** *и. бот.* Чатырчәчәкләр семьялыгыннан каурыйсыман яфраклы, сары чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек (сары төстәге буяу ясау өчен кулланыла); *русчасы:* **пастернак посевной**

**СЫЕРУ** *ф.* 1) Җиңне, балакны сызганган кебек итеп җыеру. *Җиңнәрен сыерды*

2) Итәк, чаршау, тәрәзә пәрдәсе кебекләрне сыдырып күтәрү, ачу. *Кечесе Кыш бабайның бәрәңге белән ябыштырылган химик сакалын йолкып алды, олырагы халатның билдәмәсен шытырдатып умырып төшерде, «күбәләк» галстугын сыерып алды, ә аннары, дәҗҗал булып, муенына ук менеп атланды.* Р.Гаффар. *Әтиегез алачыктан кайтып керер иде дә, бит-кулын югач, оялып кына чаршауны сыерып карар иде.* А.Гыйләҗев

3) Нык ышкып, каезлап, кубарып, тырнап эз калдыру; сыдыру, тырнату. *Аягын сыерып бетерү*

**Сыерып җибәрү** Кисәк сыеру

**Сыерып кую** Тиз генә сыеру

**Сыерып тору** Гел сыеру; хәзерге моментта сыеру

**СЫЕРЧЫК** *и. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан, чыпчыктан эрерәк, гадәттә йорт тирәсендә оялый торган, кара каурыйлы, очлы канатлы, туры томшыклы күчмә сайрар кош. *Тигез чокыр булып каралган буразналарга каргалар, чәүкәләр, сыерчыклар төшәләр, төшәләр дә, муеннарын җитез хәрәкәтләндереп, буразналардан суалчан, корт чүплиләр.* С.Рафиков. *Авылда моңа кадәр агач башларына сыерчык оялары гына хуҗа иде.* Р.Низамиев

**СЫЕ́Р ШАЛКАНЫ** *и. диал.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан игүле культура буларак азык-төлек итеп кулланыла торган икееллык үсемлек; *русчасы:* **брюква**

**СЫЕРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **сыеру**. *Брезент стенаның бер төше ике катлы кебек булып өстән салынып тора иде, Әнвәр шуның аскы почмагын тартып карады. Әһә, беркетелмәгән, бер якка җиңел сыерыла икән.* Х.Камалов. *Нинди генә куркыныч ташу булса да, нинди генә дәһшәт килсә дә, рәхимсез бозларны үз кәүсәләренә алып, ыңгыраша-ыңгыраша, сыерылып, сыдырылып, кәкрәеп бетсәләр дә, субайлар күперне бу гарасаттан саклап кала иде.* Р.Батулла

**Сыерыла башлау** Сыерылырга тотыну

**Сыерылып бетү** Тәмам сыерылу. *Битенең карарлыгы да калмаган: күгәреп, тиреләре сыерылып беткән иде.* В.Нуруллин

**СЫЕШ** *и.* Сыйдырышлык, сыешлык, сыйдырыш

**СЫЕШЛЫ** *с.* 1) Билгеле күләм сыярлык, сыйдырырлык, сыйдырышлы, сыйдырып була торган. *Батыршага бер чүмеч бал сыешлы затлы чәркә туры килде.* Җ.Рәхимов. *Хуҗа шкафтан өч литр сыешлы ак эмаль чәйнек алып су тутырды да газ плитәсенә ут өстенә куйды.* М.Насыйбуллин

2) Берәр җиргә салып куярлык; шуңа сыярлык, сыярдай

**СЫЕШЛЫК** *и.* 1) Сыю-сыйдыру күләме. *Мичкәнең сыешлыгын билгеләү*

2) Нәрсәнедер салып, тутырып кую, саклау савыты. *Колхоз һәм совхозларда үлән онын җиргә кертеп эшләнгән бетон сыешлыкларда саклыйлар. Үлән онын андый сыешлыкларда яшел үлән массасы катламы астында саклау яхшы нәтиҗә бирә.* Татарстанда терлекчелек. *Мичкәләр һәм пыяла савытларны (сыешлыкларны) бөкеле яклaрын өскә каратып утырталар.* Хезмәт иминлеге

**СЫЕШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **сыю** (күбрәк юклык формасында кулланыла). *Гамирның шатлыгы йөрәгенә сыешмый, җыр булып тышка атылырга әзер.* Х.Ширмән

2) Ярашу, килешү, бер-берсенә каршы килмәү (карашлар, принциплар һ.б.). *Сыешмас ут вә су, Хөсрәү белән без Сибик су бу афәт учагына тиз.* Котб

3) *күч.* Килешеп, тыныч яшәү; тату булу. *Ике яхшы кушылса, берен-бере кыешмас; ике яман кушылса, киң дөньяга сыешмас.* Мәкаль. *Кайбер кешеләрдә сыешу һәм сыешмау арасында көчле дошманлык бара, һәм алардагы мөнәсәбәтләр чылбырында бер-берсенә тартылу һәм читләшү чиратлаша.* Тигез гомер итегез!

4) *күч.* Билгеле вакыт аралыгында нәрсәдер эшләп өлгерү, шул вакыттан чыкмау. *[Рәмзис]: – Эшләп бетердем, Зиннәт абый, вакытка сыештым, – диде ул, шатлыклы елмаеп.* М.Хәбибуллин

◊ **Сыешмас булу** Кискен каршылыклар туу, килешә алмаслык хәлгә килү

**Сыеша башлау** Сыешу мөмкинлеге барлыкка килү. *[Гарифулла]: Өйгә сыешмый башладыгызмы әллә?* Т.Миңнуллин. *Суларны саклау чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә төп елгаларыбызда хлорид, нефть һәм*

*нефть продуктлары микъдары нормага сыеша башлаган.* Ватаным Татарстан

**Сыешып бетү** Тулысынча сыешу. *Изге китап сүзе булса да, тормыш мантыйгына бер дә сыешып бетми ул.* Г.Гыйльманов

**Сыешып тору** Хәзер яки һәрвакыт сыешу. *Атлетларныкыдай төз гәүдәле һәм тыгыз тәнле бу егетнең мускуллары ап-ак футболкасына көчкә сыешып тора.* Г.Тарханова

**СЫЗА** I *и.* 1) Яңгыр һәм кар сулары белән юылып, ашалып ясала торган, яссы төпле, яр битләре чирәм яисә куаклыклар белән капланган киң һәм тирән озынерганак. *Язын сызалардан су агу*

2) Корыган елга юлы, коры елга. *Исәпсез-хисапсыз инеш һәм сызалар, эре һәм вак елгалардан шаулап агып килгән язгы кар сулары белән тулган Идел [кузгала].* С.Сабиров

3) *диал.* Ызан, чик. *Сыза калдыру*

**СЫЗА** II *рәв. диал.* Бераз гына, тар гына ара калдырып. *Тәрәзәне сыза гына ачып җибәрү*

**СЫЗГАЛАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **сызгалау**. *Шул ук вакытта Фатих Хөсни китапның юл аслары сызгаланганын, читләренә нindидер билгеләр куелганын күрде һәм шүрли төшеп: «Менә хәзер орып бәрә инде!» – дип уйлады.* Г.Мөхәммәдева. *Аның күп җире сызгаланып кына калган.* Р.Гали

2) *күч.* Җыерчыклар белән каплану, сырлар төшү. *Ә карасаң, торсаң, Конрадның инде чәчләре дә агарды, йөзенә җыерчыклар сызгаланды, иңбашлары очлаеп чыкты, куллары сөякләнеп, кипшенеп калды.* Н.Дәүли

**СЫЗГАЛА́У** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **сызу** I. *--- миңа --- әдип белән хат язышып, аңардан рөхсәт алып, тексттагы кайбер сүзләрне, юлларны сызгаларга, хәтта кайбер җөмләләрне бераз редакцияләргә туры килгәне бар иде.* А.Шамов. *Алгарак чыгып, аякларын аерып басты, скрипкә дигән нәрсәсен ияге астына терәп, уң кулындагы нечкә таягы белән уңга-сулга сызгаларга керешә.* Г.Галиев

2) Өстән-өстән генә, нечкәләп тормыйча, аннан-моннан гына сызу. *Бүлмәдә, үзалдына нидер сызгалаган булып, әмма керфек астыннан гына Данишевның һәр хәрәкәтен күзәтеп, яссы түшле бер чандыр кыз утыра иде.* З.Фәтхетдинов. *Уң ягымда республиканың атаклы рәссамы, минем һәрбер карашымны тотып алырга тырышып, портретыма штрихлар сызгалый.* Ф.Яруллин

3) Сирәк кенә сызу; кайвакытта сызу. *Бик сирәк сызгалый скрипкасын, Сызгалый тик эштән соң, нык аргачтын.* Н.Баян

**Сызгалап алу** Тиз арада сызгалау. *Үзенә сиздермичә генә аның сурәтен, омтылышын альбомыма сызгалап аласым килә, тик моның өчен аның үзенә генә хас хәрәкәтен, торышын ачык итеп күрә алмыйм шикелле.* С.Сабиров

**Сызгалап бару** Системалы һәм эзлекле рәвештә сызгалау

**Сызгалап бетерү** Сызгалау эшен тәмамлау; нәрсәнеңдер өстен тулысынча сызгалау

**Сызгалап кую** Тиз генә сызгалау; алдан ук сызгалау. *[Ул] Өстәл тартмасыннан бер бит кәгазь алып, тиз генә нидер сызгалап куйды.* З.Фәтхетдинов. *Югарыда китерелгән истәлекнең канваларын мин 1944 елның февралендә фронтта, онытылмасын, хәтеремнән чыкмасын дип, газета кәгазеннән тупас кына ясалган блокнотыма ашыгыпашыгып сызгалап куйган идем.* А.Шамов

**Сызгалап ташлау** Кинәттән яки тиз арада сызгалау

**Сызгалап тору** Даими рәвештә сызгалау; хәзерге моментта сызгалау

**Сызгалап чыгу** Бар булганны, бөтенесен дә, башыннан ахырына кадәр, тоташ сызгалау

**Сызгалый башлау** Сызгаларга тотыну, сызгаларга керешү

**Сызгалый бирү** Үз уңае белән сызгалау эшен дәвам итү

**СЫЗГАНУ** *ф.* **1.** Киемнең җиңен яки балагын, комачауламасын, юешләнмәсен һ.б.ш. өчен, кайтарып күтәреп кую. *Анда инде тирәнрәк, җәяүләп кичәргә кирәк булса, балакны бот төбенә кадәр сызганасың.* М.Әмир. *Бу юлы аны --- ак чалбар балакларын тубыгына тикле сызганган, зәңгәр күлмәгенең җиңнәрен терсәгенә чаклы төргән юан ак изүче – эксплуататор – тал чыбык белән чыелдатып яра-яра куып чыгарды.* М.Кәрим

**2. сызганып** *рәв. мәгъ. күч.* Тырышып, бар көчеңне биреп; җиң сызганып. *Ул үзе генә сорамый, сораса, аңа байларның менә дигәннәре дә кызларын бирергә хәзер сызганып торалар.* Г.Камал. *И мактый ул колхоз басуларын, Фермаларын мактый сызганып. Басар өчен йөрәк ярсуларын Йөргән иде ул сыйланып.* Г.Афзал

**Сызгана төшү** Беркадәр сызгану

**Сызганып алу** Тиз генә сызгану

**Сызганып кую** Алдан ук сызгану

**СЫЗГАНУЛЫ** *с.* Сызганып, кайтарып куелган. *Икесе дә иңбашларына такта күтәргән, икесенең дә җиңнәре сызганулы, йөзләре якты.* Ф.Шәфигуллин. *[Немецларның] Җиңнәре терсәкләренә кадәр сызганулы.* Ж.Дәрзаман

**СЫЗГЫ** *и. махс.* Балта эшендә юну сызыгын билгеләп сызу коралы. *Сызгы тоткан столяр. Сызгы белән билгеләнгән урыннан яру*

**СЫЗГЫРА́К ЧЫПЧЫК** *и. зоол.* Чыпчык кошлар семьялыгыннан күз тирәләре кара, гәүдәсе кызгылт соры, кара канатында ак, сары, кызыл буйлар булган бүрекле сайрар кош; *русчасы:* **свиристель**. *Матурлыгы буенча карабүректән бер дә калышмый торган тагын бер төньяк кунагы бар: аны сызгырак чыпчык диләр.* Ф.Ибраһимова

**СЫЗГЫРГЫЧ** *и. к.* **сызгырткыч**. *Ушбу сызгыргыч тавышларны бирәү аулап җыйса, Барчасыннан көчлерәк бер җил нидер даулап исә.* Г.Тукай

**СЫЗГЫРТКЫЧ** *и.* Сызгыру коралы, сигнал бирә торган нәрсә. *Электричка сызгырткычы*

**СЫЗГЫРТМА** *и. диал. к.* **сыбызгы**. *Сызгыртма ясау*

**СЫЗГЫРТУ** *ф.* 1) Сызгыру авазы чыгару. *Алдым. Карасам, чыбык түгел ич бу – курай! Авызыма кабып сызгырттым.* Н.Дәүли. *Нәкъ шул чак болдыр янындагы тупылның бер ботагы шартлап сынды да һаваны сызгыртып җиргә төште.* М.Хәбибуллин

2) Төрле сызгырткычлар ярдәмендә кычкырту, сигнал бирү, кисәтү. *Поезд*

*кузгалып киткән тавышлар. Поезд әче итеп сызгырта. Тизлек артканнан-арта.* Ф.Зарипова

3) Йоклаганда яисә авырганда борын белән сызгыру тавышы чыгару. *Ул әллә кайчан борынын сызгыртып йоклап ята инде.* Г.Бәширов. *Госман эштән соң кайтып кергәндә, кадерле кунагы диванда борын яфракларын дерелдәтеп сызгыртып йоклап ята иде әле.* Э.Касыймов

4) *күч.* Урлау, чәлдерү. *Акчаны сызгырту*

5) *күч.* Ялганлау. *Шулай да хуҗа өчен генә җавапсыз калмады: – Бабай, ышанмагыз, сызгырта ул... – Юк, гүзәл кыз, чынын әйтә, – диде хуҗа кинәт.* Х.Камалов

**Сызгырта башлау** Сызгыртырга тотыну. *Безнең ротаның бер дневальные сыбызгысын сызгырта башлады, аңа бүтәннәр дә кушылдылар.* А.Таһиров

**Сызгырта бирү** Бернигә дә карамыйча сызгыртуны дәвам итү

**Сызгыртып алу** Кинәт кенә яки бер ара сызгырту. *Карт, күзләрен челт-челт йомып, чукрак кеше кебек, лейтенантның авызына карап катты, борынын сызгыртып алды һәм, кинәт нәрсәдер аңлагандай, иреннәрен бөреш-тереп әйтә куйды ---.* З.Фәтхетдинов

**Сызгыртып җибәрү** Кинәттән сызгырту; сызгырта башлау. *Мин кураемны сызгыртып җибәрдем.* Н.Дәүли. *Көтмәгәндә, җырга бөтенесе дә, хәтта арттагы машиналарда кайтучылар да кушылды, һәм егетләрнең кайсыдыр куш бармаклап сызгыртып та җибәрде ---.* Э.Касыймов

**Сызгыртып кую** Бер мәртәбә сызгырту. *Менә ул туктап калды һәм тел очы белән җиңелчә сызгыртып куйды – Абдулла аны шундук таныды.* Э.Касыймов

**СЫЗГЫРУ** *ф.* 1) Бөрелгән ирен, кысылган теш аркылы һаваны көч белән өреп үткәреп, нечкә ачы аваз чыгару. *Кепкасын кулына тотып, адым уңаена селкә-селкә, бөтен тавышы белән кычкырып җырлый: «Урманнарга керсәң, сызгырып кер, Селкенмәгән агач лай калмасын...»* Г.Әпсәләмов. *Китте бию: ялгыз бию, парлап бию, кочаклашып-күмәкләп бию, сызгырып бию, кычкырып бию!* И.Юзеев

2) Төрле кошларның яки хайваннарның сызгыруга охшаш аваз чыгарып кычкырулары, сайраулары һ.б.ш. *Мич асты ягыннан туктаусыз сызгырган, мәгәр моңарчы аның өчен барлыгы сизелмәгән өй чикерткәсе тавышы да Шәвәлинең колагын ертып киткәндәй булды.* С.Рафиков. *Күктә тургай сайрый. Аяк астында гына йомраннар сызгыра.* Н.Әхмәдиев

3) Җил яки ни дә булса зур тизлек белән һава ярып нечкә аваз чыгару, ызгыру. *Алар болгарлар кебек үк коралланганнар: барысында да тимер калкан, кылыч, сызгыра торган уклар, челтәрле көбә кигәннәре дә бар, башларында болгар очлымнары.* М.Хәбибуллин. *Ә җил көчәйгәннән-көчәя: мачталарга, вантыларга бәрелеп улый, сызгыра, дулкын сыртларыннан өзеп алган күбекләрне, тамчыларны рубка тәрәзәләренә чәчрәтә.* С.Сабиров. *Түшенә йолдызлар кадалган күктә метеорит сыман бер объект сызгырып үтте...* Х.Ибраһим

4) Сызгырып *(1 мәгъ.)* көй чыгару. *Көй сызгыру*

5) Сызгырган *(1 мәгъ.)* тавыш чыгарып хәбәр бирү, берәр нәрсә турында белдерү; әйдәү. *Нindидер ачы, шомлы сызгыру, улау тавышына уянып, айнып китте Зөһрә.* Г.Гыйльманов

6) Сызгырган *(1 мәгъ.)* аваз чыгарып соклануны белдерү // Сызгырган *(1 мәгъ.)* аваз чыгарып хурлау хисен белдерү. *Докладчыны сызгырып бүлдерү*

7) *күч.* Мохтаҗлык, авырлык кичерү. *Кайчандыр типтереп яшәгән кешенең сызгырып йөрүе*

◊ **Сызгырып калу** Аптырап, берни эшли алмау хәлендә калу. *Моннан ары каршы килеп кенә кара. Әнкәй дип тормам. Башка чыгармын, сызгырып калырсың.* С.Рафиков

**Сызгыра башлау** Сызгырырга тотыну. *Нотык тотучының фикере белән --- килешмәгән очракта, аны инкяр итеп, бердәм рәвештә: «Азатлык!» – дип кычкыра, сызгыра башлый.* З.Мәхмүди

**Сызгыра бирү** Бернәрсәгә карамастан сызгыруны дәвам итү. *Сызгыра бирсеннәр, төп тамашачы сине барыбер яхшы кабул итәчәк.* Р.Батулла

**Сызгырып алу** Бераз сызгырган тавыш чыгару

**Сызгырып җибәрү** Кинәт кенә сызгыру; сызгыра башлау. *Ул бер-ике адым алга атлады да тагын сызгырып җибәрде.* Г.Гобәй. *[Фёдор Лукич] Карашын тиз генә чиркәүгә күчерде. Түзмәде, сызгырып җибәрде ---.* З.Фәтхетдинов

**Сызгырып йөрү** Гел сызгыру. *Берничә көн ялгыз-ярым паркта, чокырларда сызгырып йөрдем, хәтта Арча кыры зиратына барып чыккаладым.* Г.Әпсәләмов. *Нишләп син, кызыкай, берүзең урманда сызгырып йөрисең?* Г.Гобәй

**Сызгырып кую** Кыска гына, бер тапкыр, кинәт сызгыру. *Якында гына йомран сызгырып куя...* М.Хәбибуллин. *Зәки сандугач турында туктап, аңар көлемсерәп карап торды да сандугач шикелле итеп үзе дә сызгырып куйды.* Х.Мөҗәй

**Сызгырып тору** Даими, регуляр рәвештә яки хәзер сызгыру. *Тышта җил әллә нәрсәләргә генә шакылдатып сызгырып тора, әллә нинди чинаган, улаган тавышлар ишетелгән кебек була иде...* Ш.Камал

**СЫЗГЫРУЛЫ** *с.* 1) Сызгыра торган. *Шул мәлдә үк укчылар тарафына сызгырулы ук очты һәм нәкъ Айбибинең улы Ибраһимга таба.* М.Хәбибуллин

2) *лингв.* Һава агымы зур тизлек белән тешләр арасыннан үткәндә ясала торган (аваз тур.). *Сөйләштә тел очы [ч] авазы – аффрикат, ул шартлаулы тартык һәм сызгырулы тартык «ч» элементлары кушылып ясала: пытчак – пычак, тчыбык – чыбык.* Ф.Баязитова

**СЫЗГЫРЧЫК** *и.* 1) Эченнән һава өреп үткәргәндә сызгыру тавышлары чыгара торган әсбап, җайланма

2) Сызгырырга яратучы кеше

3) Кайбер кошлар һәм кимерүчеләрнең аерым төрләрен белдерә. *Сызгырчык тилгән*

**СЫЗГЫРЫК** *и. диал.* **1.** Сызгыру тавышы

**2.** *с. мәгъ.* Сызгырып исә торган. *Сызгырык җил урманга килеп керә дә ботакларда коелмыйча калган кызгылт*

*бөрчекле яфракларны үҗәтләнеп йолкый башлый.* М.Рәфыйков

**СЫЗГЫРЫНУ** *ф.* Үзалдына сызгыру. *Машинага җил иярде, ул, шаян малайлар кебек сызгырынып, тәрәзә артында йөри.* К.Кәримов. *Үзем аны күрмәгән булып кыланам, сызгырынам, камчы шартлатам.* М.Маликова

**Сызгырына бирү** Бернәрсәгә игътибар итмичә сызгырынуны дәвам итү

**Сызгырынып йөрү** Даими, гел сызгырыну

**Сызгырынып тору** Бертуктаусыз сызгырыну

**Сызгырынып утыру** *к.* **сызгырынып тору**

**СЫЗГЫРЫШ** *и.* 1) Сызгыру рәвеше; сызгыру процессы. *Сызгырышы бик үзенчә аның*

2) Күпләп сызгырган тавышлар. *Ләкин тавыш, сызгырыш, отыры көчәеп, төрмәне каплады.* И.Туктар. *Ут сүнеп, кино өзелгәч, клуб эчендә сызгырыш, кычкырыш, дөбердәтеп аяк тибеш һәм сугыш башлана.* К.Кәримов

**СЫЗГЫЧ** I *и.* 1) Шырпы кабының шырпы сызып кабызу өчен, махсус матдә ябыштырылган ян өслеге

2) *диал.* Шырпы

**СЫЗГЫЧ** II *и.* Бер башыннан икенчесенә ат кылы (хәзер металл җеп) тарттырып ныгытылган, шуның белән уен коралы кылларына сызып аваз чыгара торган таякчык; кәманча; *русчасы:* **смычок**. *Уенчыбыз, скрипкасын алып, Сызгыч белән кылга сыздыргач, Бакча тулып акты көй чишмәсе, Туйга килгән гүя сандугач...* М.Фәйзуллина

**СЫЗГЫЧ** III *и.* Туры сызык сызу өчен хезмәт итә торган тигез кырлы, озынча юка әсбап; линейка. *Балаларның башы яңадан карта өстенә иелде. Яңадан сызгычлар, җәзбәләр кәгазь өстендә шуып йөрде.* Л.Ихсанова. *Бу системада ноктаның торышын өч үзара перпендикуляр каты сызгыч рәвешендәге күчәр аша билгеләп була.* Физика

**СЫЗДЫ́-БЫЗДЫ** *с. к.* **сыздый-быздый**

**СЫЗДЫ́Й-БЫЗДЫЙ** *с.* **1.** Аннан-моннан гына башкарылган, тырышып эшләнмәгән, тәртипсез, ямьсез (язу, рәсем, бизәк, буяу һ.б.). *Сыздый-быздый рәсемнәр*

**2.** *рәв. мәгъ.* Ямьсез итеп, иренеп, игътибарсыз, җиренә җиткермичә (буяу, сызу һ.б.ш.). *Сыздый-быздый гына буялган идән*

**СЫЗДЫРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сыздыру**. *Аның каравы икенче музыкантның скрипкада сыздыртканлыгын ул шунда ук төшенде.* А.Расих. *Яхшы чакта сыздырт моннан.* Р.Батулла

**Сыздырта бирү** Бернәрсәгә игътибар итмичә сыздырту

**Сыздырта төшү** Бераз сыздырту

**Сыздыртып алу** Тиз сыздырту; бераз гына сыздырту. *«Син дә боек, мин дә боек, күңелләрне ни ачар? – дип эндәште ул баянга. – Ичмасам, бер сыздыртып алыйк әле без синең белән...»* Э.Касыймов

**Сыздыртып җибәрү** Кинәт сыздырту

**СЫЗДЫРУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сызу** I (*1–7, 10–12 мәгъ.*). *Семён икенче тапкыр больницада ятканда, күршесе аны фатирдан сыздырып, тышкы ишекнең йозагын алыштырып куйган.* М.Маликова

2) Чыбык, чыбыркы, камчы һ.б.ш. нәрсә белән сугу. *Дилбегә белән сыздыру*

3) *күч.* Уен коралында оста, матур итеп уйнау; сайрау, җырлау һ.б.ш. *Юк, ялгышмыйм, чынлап, кайдадыр тальян гармун моңлы гына сыздыра.* Н.Дәүли. *Безгә якынайган саен, скрипкә сыздыруы да, бүтән тавышлар да ачыграк ишетелә башлады.* Г.Бәширов. *Ә ул чын безнеңчә татар көен – «Тәфтиләү»не сыздырырга тотынды.* М.Хәбибуллин

4) *күч.* Таю, качып китү. *Камышлар арасыннан сыздыру*

**Сыздыра бирү** Бернәрсәгә игътибар итмичә сыздыру

**Сыздырып алу** Тиз генә, бераз гына сыздыру. *Тегендә, авыл эчендә, йөгәнсез гармун кинәт хәтәр-хәтәр иттереп сыздырып алды да тынып калды.* Э.Касыймов. *Башкалар җырлаганда, тавышы бөтенләй диярлек басылып калса да, ике җыр арасында ул берүзе дә гаҗәеп моңлы сыздырып ала һәм җырчыларга яңа көйне башлап җибәрергә дә шәп кенә ярдәм итә иде.* С.Сабиров

**Сыздырып җибәрү** Сыздырырга тотыну. *Ускәчрәк, бакчабызда үсеп утырган бу карт каен тузы белән коралланып, кызлар янына баргаладык. Бер сызгырып, сыздырып җибәрәсең!..* Г.Гыйльманов. *Берничә җырдан соң гармунчы егет, күңелләрне җилкендереп, бию көен сыздырып җибәрә.* Р.Кәрами

**Сыздырып кую** Кисәк кенә сыздыру. *Ниһаять, музыка өзелде, баян нык кына сыздырып куйды, бию туктады.* М.Маликова

**Сыздырып тору** Еш, һәрвакыт сыздыру

**СЫЗДЫРУ** II *ф. йөкл. юн. к.* **сызу** II. *Ул көннәрдә аның йөрәк маен тик бер генә нәрсә – институтта калу-калмау мәсьәләсе сыздырып торды.* В.Нуруллин

**СЫЗДЫРЫП** *рәв.* Йөрәкләргә үткәреп, күңелләрне биләрлек итеп, оста, матур итеп. *Шактый көтте Шамил, ерак та түгел, эч пошырып, сыздырып гармун уйнады.* Я.Зәнкиев. *Һәр елны, авылыма кайткан саен, мин җиде төн уртасында, сыздырып гармун уйныйуйный, урам әйләнәм.* И.Юзеев

**СЫЗЛАВЫК** *и.* 1) Сызлый торган үлекле вак шеш. *Агач көлен сызлавык өстенә сибәләр.* Мөселман гаиләсе календаре

2) *күч.* Әрнеп, борчылып тору халәте. *Ләкин күңелендәге бу сызлавыкны ерак юлга алып чыгып китсә, кайтып кергәнче тынгы белмәячәк иде Җәмилә Закировна.* М.Маликова. *Күңелендәге бетмәс сызлавык, тамак төбендәге үтмәс төер аңа бушанып, ачылып китәргә һич ирек бирми торалар иде...* Г.Гыйльманов

**СЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Сызлату, авырттыру, сызлауга сәбәпче булу. *Тәнендә утырган дошман минасы кыйпылчыклары кай кичләрне аны керергә тишек тапмастай әче сызлау белән сызландыра.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Борчу, рухи газап бирү. *Мондый очрашулардан калган хис атна буе йөрәкне сызландыра, бу сызлану икенче очрашуга кадәр җитә иде.* М.Маликова. *Шулай да кызның гомерендә беренче тапкыр күңеленә корт кергән, һәм ул корт, аның җелекләрен*

*сызландырып, сулык-сулык суырырга керешкән иде...* Э.Касыймов

**Сызландыра башлау** Сызландырырга тотыну

**Сызландырып тору** Бертуктаусыз сызландыру

**СЫЗЛАНУ** I *ф.* 1) Нәрсә дә булса сызлап, авыртып газаплану, тынычсызлану. *Элегрәк Хәниф абый төннәр буе сызлана торган иде.* Н.Дәүли

2) *күч.* Кайгыру, борчылу, ачыну, әрнү, рухи газаплану. *Уйлар, нарат сагызы кебек, йөрәккә үк сыланганнар, авырттыралар, сызландыралар.* Э.Касыймов. *[Кыз] Һәдия сыман, күршекүлән юк дип, хәбәр-хәтер килми дип пошынмый, шушында урман эчендә гомерем заяга үтә дип тә сызланмый.* Г.Якупова

**Сызланып алу** Берара, бераз сызлану

**Сызланып китү** Кинәт сызлану

**Сызланып кую** Тик торганнан, кисәк сызлану. *Йөрәк дигәнең сызланып куйса да, артык әһәмият бирмәгән шикелле китеп бардым.* Ш.Маннур

**Сызланып тору** Һәрвакыт сызлану

**СЫЗЛАНУ** II *и.* 1) Авырту, сызлау, әрнү. *Нинди сызланулар, нинди тән газаплары кичерүе йөзенә чыккан аның.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Кайгы, хәсрәт, рухи газап. *Хәер, аның һөнәре шул, операция вакытында сызлануларны җиңеләйтүче, кешенең җан сагында торучы, анестезиолог Наил Хәйдәрович.* М.Маликова. *Күңелем, җәйрәп яткан шушы тын күлдәй, сагыш, сызлану, нәүмизлек белән тулы...* З.Гиниятова

**СЫЗЛАНУЛЫ** *с.* Сызлануны белдерә торган; сызлану белән тулган, сызланганда чыга торган. *Ишетү генә түгел, әллә нинди бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсым да килеп китте.* Ә.Еники. *Шул сугыш аркасында сызланулы көннәрне, саташулы төннәрне күп кичердем мин.* Г.Госман

**СЫЗЛАТКЫЧ** *с.* 1) Сызлау, авырту китерә торган

2) *күч.* Әрнергә, борчылырга этәргән. *Аның күңелен нindидер аңлаешсыз бушлык, канәгатьсезлек хисе биләп алды, нindидер сызлаткыч нәрсә йөрәгенә авыр таш булып ятты.* М.Галәү

**СЫЗЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сызлау**. *[Сабадырёв] Шушы кыз эзенә басабаса үзенең ник килгәнен белсә дә, хатын-кыз назына сусавы түзә алмаслык дәрәҗәгә җитеп бөтен буыннарын сызлатса да, бәхетнең бу кадәр якынлыгы аның өчен көтелмәгән бер хәл иде.* З.Фәтхетдинов. *Тән буйлап кайнар кан акканы, күкрәкләргә сызлатып җылы сөт тулганы сизелә.* Э.Шәрифуллина

**Сызлатып бетерү** Нык сызлату

**Сызлатып җибәрү** Кинәттән сызлату

**Сызлатып йөрү** Озак, дәвамлы рәвештә сызлату. *Аткан да булыр иде [Абдулла], өченче елгы печән өсте ачык зиһенен бөтенләй чуалтты, тәмам иләсләндерде егетне, гомере буена йөрәген рәхәт кенә сызлатып йөриячәк җәрәхәт калдырды.* Җ.Рәхимов

**Сызлатып кую** Кинәт сызлату

**Сызлатып тору** Һәрвакыт сызлату

**СЫЗЛА́У** I *ф.* Тән әгъзалары турында: әрнеп, авыртып, борчылып тору. *Эчем авырта, аркаларым сызлый, сөякләрем сыкрый иде.* Г.Исхакый. *Тукмалган тәне һаман сызласа да, күңеле көр дип әйтерлек иде.* Я.Зәнкиев

**Сызлап алу** Берара, кыска вакыт сызлау

**Сызлап йөрү** Һәрвакыт сызлау

**Сызлап китү** Кисәк сызлау. *Ләкин бармагы түгел, йөрәге сызлап китте аның.* Г.Иделле

**Сызлап кую** Кыска вакытка сызлау. *Иелгәч тән-аяклар сызлап куйды, һәм куе сакал баскан битнең тырналган урыннары әчетте.* З.Хәким. *Аның аркасы буйлап салкын йөгерде, әйтерсең кемдер ялангач тәненә салкын боз тидереп үтте, аяклары сызлап куйгандай булды.* Р.Кәрами

**Сызлап тору** Даими рәвештә сызлау. *[Хатын:] Әйткән идем мин аңа, билем сызлап тора дип, бармады бит...* Э.Касыймов. *Эчтәге яра тиз генә төзәлми ул, һаман сулкылдап сызлап тора.* Х.Камалов

**Сызлый башлау** Сызларга тотыну. *Теш сызлый башлады*

**СЫЗЛА́У** II *с. к.* **сызлаулы**. *«Әнкәй таза түгел, буыннары сызлау, эшләве заводта, төнге каравылда тора. Булган терәкләре – мин!» – диде кыз.* Я.Зәнкиев

**СЫЗЛАУЛЫ** *с.* Сызлый торган, даими сызлап торган. *[Фазылҗан абзый] Капка келәсенә тотынуга, аякларында кинәт сызлаулы хәлсезлек сизеп тукталып калды.* Р.Төхфәтуллин

**СЫЗЛАУСЫЗ** *с.* Сау-таза, сызламый торган. – *Вәт, кызым, сыйладың, аягың-кулың сызлаусыз булсын! – ди ул.* Ш.Янбаев. *Янында ни кылырга белми аптырап торган сестрага ул: – Рәхмәт. Бала, кулларың сызлаусыз булсын. Әйбәт карадың, – диде.* М.Хәбибуллин

**СЫЗЛАУЧАН** *с.* Еш кына сызлый торган (тән әгъзалары тур.). *Өшегән урын, үз халәтенә кайтканда, бик каты сызлаучан була.* Г.Галиев

**СЫЗМА** I *с.* **1.** 1) Сызып эшләнгән. *Сызма план*

2) *мат.* Күләмле фигураларны яссы проекция нигезендә өйрәнә торган. *Тиз арада үзенчәлекле, югары сыйфатлы физика (4 том), сызма геометрия, гомуми химия, икътисад һәм финанс, трактор һәм автомобиль, төзелеш буенча дәреслекләр дөнья күрде.* Мәдәни җомга

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сызым, график, схема, эскиз. *Никулин тарафыннан эшче сызмалар да әзерләнеп бетерелә.* А.Алиш

2) Гомуми, өстән-өстән генә эшләнгән, башлангыч рәвешендә генә булган хезмәт, әсәр, картина, рәсем һ.б.; каралама

**СЫЗМА** II *с. махс.* 1) Рәт араларын эшкәртеп игелә торган. *Сызма культуралар. Сызма чәчү әйләнеше*

2) Шундый ысулга нигезләнгән. *Игенчелектә сызма системага күчү*

**СЫЗМАЛЫ** *с. к.* **сызма** II. *Сызмалы чәчү агрегаты*

**СЫЗУ** I *ф.* 1) Сызык ясау, үткәрү; сызык билгесе төшерү; сызык рәвешле эз калдыру

2) График, схема, сызым, эскиз һ.б.ш.ны ясау. *Исәп-хисапны да, карта сызу эшләрен дә үзем генә башкарырмын.* З.Зәйнуллин

3) Ашыгып, берничә сүз генә язу. *Гаризага бер генә сүз белән сызып резолюция салу*

4) Язылганның яки рәсем итеп һ.б. төшергәннең дөрес түгеллеген, кирәк түгеллеген белдереп сызык үткәрү. *Гомәр дә кульязмалар актара, яза, сыза, редакцияли башлады.* А.Шамов

5) Исемлектән төшереп калдыру, кертмәү. *Гыймазов тәкъдиме буенча, бу хуҗалыкларны кулаклар исемлегеннән сызып ташладылар.* С.Рафиков. *Шул рәвешчә, әнә Газыйм Дардиевны бандитлар үзләре үк «исемлектән сыздылар».* З.Фәтхетдинов

6) Ут кабызу өчен сыдыру, ышкып җибәрү (шырпыны). *[Ул] Блиндажга кемнеңдер килеп керүен, шырпы сызуын да сизми.* Ф.Галиев. *[Һадия] Чоланда яткан гәүдә ягына башын бормыйча, күз дә салмыйча, кесәсеннән кап чыгарып шырпы сызды да шул якка ташлады.* Г.Якупова

7) Яру, үткәрү, ясау. *Беренче бураznаны сызу. Ызан сызу*

8) Берәр культураның рәт арасын көпшәкләү, йомшарту, кумү, өю өчен буразна үткәрү. *Рәт араларын сызу. Бәрәңгене сука белән сызу*

9) Скрипка сызгычын ышкып йөртеп көй чыгару; уйнау. *Хәлим тизләтә башласа, Шәйхаттар бабай туктатты: – Бер көйгә генә, – диде ул, – скрипка сызган шикелле генә...* Г.Гобәй

10) *күч.* Элек әйтелгән яки язылган фикерне, кагыйдәләрне яраксызга чыгару, бетерү, гамәлдән чыгару, инкяр итү. *Кичә язылган кагыйдәләрне бүген сызу*

11) *күч.* Камчы, чыбык, чыбыркы, сыгылмалы әйбер белән сугу, сыдыру. *Камчы белән берне сызу. Чыбык белән сызып җибәрү*

12) *күч.* Киләчәккә бару юлын, тормыш юнәлешен билгеләү, күрсәтү; план кору. *Инде башка бик күп халыклар да ул сызган якты юлга чыктылар һәм азат, шат яшиләр.* С.Сабиров

13) *күч.* Бик оста, бик матур итеп уйнау, җырлау, сайрау. *– Секретыбыз юк югын, әмма бер шартыбыз бар, – диде Нәдерша. – Гармуныңны сызар булсаң гына, безнең яннан сызмассың.* И.Туктар

14) *күч.* Тиз генә качып китү, таю. *Бу чагында кызарып, яныр сөйләгән Сәгыйтовның да, усал карчыкның чыгып сызуын күреп, миенә кайнарлык йөгерде ---.* С.Рафиков. *Семёновка шул гына кирәк булган да инде. Эшен бетергәч, ул районга сызу ягын караган.* М.Маликова

15) **сыз, сызыгыз** *боер. форм. күч.* Батыраеп куу, китүне таләп итү (куып җибәргәндә әйтелә). *[Амур:] Егетләр, Саҗидә белән Диләфрүз сезне көлкегә калдырырга җыеналар, сызыгыз моннан.* Т.Миңнуллин

**Сыза бару** Эзлекле рәвештә, рәттән, тоташ сызу

**Сыза башлау** Сызырга тотыну. *Әби, таягын алып, җиргә ниндидер тамгалар сыза башлады.* Х.Әбделмәнов

**Сыза бирү** Бернәрсәгә карамыйча сызуны дәвам итү

**Сыза килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә сызу

**Сыза тору** Ниндидер процесс узганчы, шуның белән берьюлы сызу

**Сыза төшү** Тагын бераз сызу

**Сызып алу** Тиз генә, бер тапкыр сызу, сызылган (эшләнгән) хәлгә китерү. *Бүлмәдән чыгып киткәнче, [Зөһрә] бүлмә буйлап йөри, кызыксынып ниндер карый, бармагы белән шкаф киштәләре буйлап сызып ала – тузанлы...* С.Гаффарова

**Сызып ату** Кинәт, тиз арада яки ачу белән сызу

**Сызып бару** Рәттән сызу, эзлекле рәвештә сызу. *Ул ниндидер калын китап укый, кайбер җөмләләрнең асларына сызып бара.* М.Мәһдиев

**Сызып бетерү** Ахырына кадәр сызу; бөтенесен дә сызу

**Сызып җибәрү** Кинәттән сызарга тотыну

**Сызып калу** Сызарга өлгерү, вакытында сызу

**Сызып кую** Алдан сызылган хәлгә китерү; бер мәртәбә сызу. *Рафис «экспериментал» сүзенең астына сызып куйды да, нинди сүздер, укытучыдан сорарга кирәк булыр, диде, аннары укуын дәвам итте.* Х.Хәйруллин. *Ялан авылына барып боз озатканда, алар бүген үзләренең төп мәсьәләсен хәл итәргә, киләчәккә юллар сызып та куярга тиешләр иде.* Я.Зәнкиев

**Сызып ташлау** Кинәт, тиз сызу. *Әйе, мине ярлылар-юксыллар кеңәгәсеннән сызып ташлагыз, минәйтәм.* С.Рафиков. *[Дәүләтов] Язды-язды да, туктап, язганнарын сызып ташлады.* И.Низамов

**Сызып тору** Даими, регуляр рәвештә яки хәзер сызу

**Сызып утыру** Әле, күз алдында сызу

**Сызып чыгу** Башыннан ахырына кадәр сызу. *Рәсемне фанерга күчергәч, пычкы белән киселергә тиешле урыннарны, катлаулы бизәкләрне эшләгәндә буталмас өчен, карандаш белән сызып чыгалар.* Йорт эшләре

**СЫЗУ** II *ф.* 1) Эрү, изрәү. *Май сызу*

2) Пыскып тору, пыскып яту. *Учакта күмер сызып ята*

3) Әкренләп кимеп бару һәм юкка чыгу; эрү. *Сызып яткан кар*

4) *күч.* Какчалану, чандырлану, ябыгу. *Гәүдә күзгә күренеп сызу*

5) *күч.* Берәр кайгы-хәсрәт, сагыш, борчу сәбәпле әрнү, әрнешү (йөрәк, күңел). *Диләрам! Җәмилә Закировнаның йөрәге сулкылдап куйды. Диләрам! Менә кем өчен сыза икән бит аның күңеле!* М.Маликова. *Соңгы вакытта Таҗылбанат бу өметнең өзелүен сизә, моңа эчтән сызып кына кайгыра башлаган иде.* М.Хәбибуллин

**Сыза бару** Торган саен ныграк сызу. *Күз алдында әкрен генә сыза барган шагыйрьгә һични ярдәм итә алмаганына үзен гаепле саный кебек.* Р.Батулла

**Сыза башлау** Сызарга тотынырга. *Өйгә чыккач, менә кара мәчемез көннән-көн арыклана, көннән-көн сыза башлады.* Әкият

**Сыза бирү** Бернигә карамый сызу. *Ә икенчеләре тормышларыннан кычкырып зарланмыйлар, тавышсызтынсыз гына эчтән сыза бирәләр.* Татар әдәбияты

**СЫЗУЧЫ** *и.* Сызык ясау, сызу I (*1, 2 мәгъ.*) эшләрен башкаручы

**СЫЗЫК** I *и.* 1) Нечкә генә төшерелгән озынча эз. *Сөт беләнме, бүтән сыекча беләнме, әллә нинди эзләр, сызыклар төшерелгән.* З.Фәтхетдинов. *Аяк киеме кырык икенче үлчәмле булса кирәк, табанындагы сурәт тар гына*

*аркылы сызыклар рәвешендә, үкчәләре арттан бераз ашалган.* Ф.Галиев

2) Берәр нәрсә артыннан калып барган нечкә эз

3) Берәр нәрсәнең читен билгеләп, аерып торган шартлы билге, чик. *Сугыш сызыгына терәлеп торган лазаретны бәяли торган сүзләр телләрдә юк...* Я.Зәнкиев. *Кич белән Әнвәрнең температурасы кырык сызыгын узып китте.* Х.Камалов

4) *иск.* Юнәлеш, юл. *Телеграф сызыгы. Тимер юл сызыгы*

5) *грам.* Озын горизонталь туры формасындагы тыныш билгесе; тире. *Автор сүзләре белән туры сөйләм арасында сызык кую*

6) *мат.* Ике ноктаны тоташтырган эз. *Чөнки сызык ул – математик төшенчә генә, һәм, ноктаның өлешләре юк, дигән аксиомадан чыгып, сызыкның да киңлеге һәм, әлбәттә, күләме юк.* З.Мурсиев

7) Җыерчыклану һ.б. сәбәпләрдән барлыкка килгән озынча эз, сыр, юл. *Ә инде каш арасындагы сызыкларын, уйчан күзләрендәге януны игътибар белән күзәтсәң, бу солдат ниндидер көчле кичерешләр утында кайный, дип уйламыйча кала алмыйсың.* И.Туктар

8) Чалым, тышкы линия (йөз тур.). *Урамдагы утлардан төшкән яктылыкта аның вак йөз сызыклары аермачык булып күренә, уч төбедәй ак чырай кечкенә башка ябыштырып куелган кебек тоела иде.* Р.Зәйдулла. *Мәрхүмә кырык яшьләр тирәсендәге чибәр генә хатын булган икән. Йөз сызыклары бик нәфис.* М.Маликова

9) Җиргә шакмаклар сызып, шунда сикереп уйнала торган балалар уены. *Март кояшы киптереп өлгергән тротуарда шәһәр балалары сызык уйный.* С.Сөләйманова

10) Армиядә хәрби составның җиңенә, күкрәгенә яки погонына тегеп куелган тар тасмадан гыйбарәт аеру билгесе. *Элекке ефрейтор, хәзер инде погоннарына тагын бер кызыл сызык өстәгән Виталий Кузьмич Антипов, кайтуы белән Миңнулланы кочаклап алды.* Г.Әпсәләмов. *Ул андагы үзе генә күргән сызыклар аша киләчәкне юрый, сөяктәге сызыклар язмыш юлларына барып тоташа иде.* Р.Зәйдулла

11) *күч.* Берәр үзлек, үзенчәлек, сыйфат, билге. *Иҗатының икенче төп сызыгы – Газиз Мөхәммәтшин күпчелек әсәрләрен яшьләргә-балаларга багышлады.* А.Гыйләҗев

12) Билгеле эзлеклелек, юнәлеш, линия. *Әйтергә кирәк, әсәрнең сюжет сызыгы классицизм нәфасәтенең таләпләренә дә уңышлы гына яраштырылган, Буало тарафыннан билгеләнгән критерийлар бу әсәрдә чиксез тәкъдир ителә.* К.Гыйззәтов. *Үзенә ара-тирә күз салгалап, төсенә елмаю сызыклары чыккан буфетчы кызга Сәмигулла игътибар бирмәде.* С.Рафиков

**СЫЗЫК** II *и.* Туңмайны эреткәндә төер-төер куырылып кала торган май ярылары. *Вакыт-вакыт аларга барып, көне буена эшләү бәрабәренә мае сыгылган сызык яки калдык ашамлык сыныклары алып кайтуларын исәпкә алсаң?* М.Әмир. *Шәвәли көл җыеп йөргәндә, чыннан да, күп өйләрдә аны кыстап ашарга утырталар: кайсы сызык белән сыйлый, кайсылары агач бадьян белән кырыккарта куя, кайсы кыздырылган бавыр китерә иде.* С.Рафиков

**СЫЗЫКЛЫ** I *с.* **1.** Өстенә сызык I (*1 мәгъ.*) сызылган; сызыклары булган. *Бәхете бар икән: кар өстенә иртәнге якта гына салынган янәшә өч сызыклы эзгә очрады.* М.Рәфыйков. *Сыек яшькелт тышлы, эче шакмаклы кыек сызыклы дәфтәр.* М.Мәһдиев. *Ул апак күлмәктән, куе зәңгәрсу сызыклы галстуктан иде.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ. к.* **сызык** I (*9 мәгъ.*). *Сызыклы уйнау*

**СЫЗЫКЛЫ** II *с.* 1) Сызык (II) салып әзерләнгән. *Бик юмартланып китмә, әнә аларга сызыклы умач җитеп ашкан.* З.Зәйнуллин

2) Эреткәндә сызыгы (II) күп чыга торган (май тур.)

**СЫЗЫКЛЫ́-СЫЗЫКЛЫ** *с.* Өстендә сызыклар булган. *Сызыклы-сызыклы яфрак*

**СЫЗЫ́К-СЫЗЫК** *с.* Бик күп сызыклар белән капланган; сызыклардан гыйбарәт. *Такта араларыннан айның ак шәүләләре сузылып, җир идәнгә сызык-сызык яктылыклар төшәгән иде.* Ш.Камал

**СЫЗЫКЧА́** *и.* 1) Кыска гына сызык I (*1, 6 мәгъ.*)

2) *грам.* Парлы сүзләрнең компонентлары арасына һәм сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә куелып, бер яктан да буш ара белән аерылмый торган ярты сызык I (*5 мәгъ.*) озынлыгындагы тыныш билгесе; дефис. *Тик алар кушылып түгел, ә сызыкча аша язылырга тиеш иде: су-үсем, кабилә-ара һ.б.* Х.Сарьян. *Сүзләрнең кушылып, аерым яисә сызыкча аша язылышы хәзергедән нык аерыла.* Б.Хәкимов

**СЫЗЫ́КЧА** *с. мат.* Озынлыкка һәм шуңа бәйле зурлыкларны үлчәүгә мөнәсәбәтле; *русчасы:* **линейный**. *Әгәр корылманы хисаплау өчен төзелгән барлык тигезләмәләр (тигезләнеш, геометрик һәм физик тигезләмәләр) сызыкча булсалар, хисаплау схемасы сызыкча дип атала.* Корылма механикасы. *Ике үзгәрешлеле сызыкча тигезләмәләр графигы, үзгәрешлеләр алдындагы коэффициентларының берсе генә нульгә тигез булмаса да, туры сызык була.* Алгебра

**СЫЗЫЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сызу** I

2) Сызык шикелле булу. *Аның бер явызлыгын мәңге онытасым юк: әле бүгенге кебек исемдә, ул вакыт әле миңа сызылып кына кара мыек чыгып килә иде.* Г.Толымбай

3) Таң, шәфәкъ турында: беленә, күренә башлау. *Кич белән безнең пехотабыз бер авылны сугышып ала. Ә таң сызылып килгән чакта, авылга артиллеристлар да килеп керә.* Г.Әпсәләмов. *Бина эче сызылып таңнар атар алдыннан була торган эңгер-меңгердә калды.* Ә.Гаффар

**Сызыла бару** Торган саен ныграк сызылу

**Сызыла башлау** Сызылырга тотыну

**Сызыла бирү** Бернигә карамый сызылу

**Сызыла төшү** Беркадәр сызылу; бераз сызылу

**Сызылып бетү** Барысы да сызылу

**Сызылып килү** Беленер-беленмәс сызылу; аз-азлап, тигез сызык торыш алу. *Ул як-ягына каранды. Таң сызылып*

*килә. Камера эче караңгы, шыксыз.* И.Туктар

**Сызылып китү** Сызып куйган кебек хәлдә, торышта булу. *Озынча алсу йөз, сызылып киткән кыйгач кашлар, бөгелеп килгән озын керфекләр.* Ф.Бәйрәмова

**Сызылып тору** Әле, күз алдында сызылу; сызылган кебек хәлдә булу. *Йолдыз, күз ачып йомганчы үтеп китеп, офыкта югала. Аның эзе бер мизгел һавада сызылып тора.* Г.Гобәй. *Минем кызымның кашлары сызылып тора, бит очлары чокырлы, чәч толымнары озын.* М.Насыйбуллин

**СЫЗЫЛУ** II *ф.* 1) Берәр нәрсә аркылы бераз гына сарку. *Ярадан кан сызылу*

2) *күч.* Ерактан бик тынык кына ишетелү. *Капкачын ачсаң, скрипкада уйнаган кебек гаҗәеп моңлы көй сызыла.* С.Сөләйманова. *Сәгатьләр үтә, шул ук көй һаман сызыла, син һаман җырлыйсың.* К.Тимбикова

3) *күч.* Борчылу, сагышлану, авыру, тынычсызлану, әрнү

**Сызыла бару** Торган саен күбрәк, ныграк сызылу

**Сызылып китү** Кинәт сызылу. *Юк, аерылышу моңсулыгы гына түгел бу, тирәнрәк сагыш иде. Ильяс моны сизде, йөрәге сызылып китте.* И.Низамов

**Сызылып кую** Кыска гына вакытка сызылу хәле кичерү

**Сызылып тору** Даими, һәрвакыт сызылу

**СЫЗЫЛЫШ** *и.* Сызылу рәвеше. *Күз карашында, ирennәренең нык сызылышында мин аның төпле холкын сизеп алдым.* Г.Әпсәләмов

**СЫЗЫМ** *и.* 1) Яссылык өстендә сызыклар белән бирелгән сурәт, график, схема; сызып эшләнгән хезмәт. *Көзгегә килеп чәч тарый башласам, [күзләр] көзгедән җемелдиләр кебек, эштә сызым өстенә иелсәм, ак кәгазь битендә күренәләр, кайтып бәрәңге әрчергә тотынсам, сулы табактан карыйлар.* Л.Ихсанова. *Алар Әнвәрнең сызым әсбапларын искә төшерделәр.* М.Маликова

2) Сызым сызу эшләре турындагы фән тармагы; *русчасы:* **черчение**. *Юкса, моңа кадәр аларга бу фәннәр, шул исәптән сызым дәресләре кермәде.* Ватаным Татарстан

**СЫЗЫМТА** *и.* Силуэт, берәр нәрсәнең тышкы рәвеше, контуры. *Сызымтасы белән үгезгә охшаган зур таш*

**СЫЗЫМЧЫ** *и.* Сызым сызучы, шул эштә эшләүче. – *Ул хәзер иҗат кешесе буларак үзенә ышанычын югалткан. Хезмәткәргә – гади сызымчыга әйләнеп калган, – диде ул.* Л.Ихсанова. *Газиз Сәрмәдиясеннән калып, ялгыз каз кебек каңгырап йөргән көннәрендә, архитектура бүлегенә яңа сызымчы алдылар.* Ә.Салах

**СЫЙ** *и.* 1) Кунаклар чакырганда, бәйрәмнәрдә әзерләнә торган затлы ризык. *Чыннан да, көнгә өч тапкыр токмачлы аш, ярты кило ипи – хәзерге заман өчен, Хәбир бабай әйтмешли, кода сые бит ул.* В.Нуруллин. – *Тагын нинди сый кирәк? Кара бу табынны! – диде Нәкыя. – Аннары тагы, нинди кунак инде мин?* И.Низамов. *Мондый сыйны аның үз гомерендә беренче күрүе иде.* Х.Ибраһим

2) Ашамлык, ризык. *[Сыерчыклар, чыпчыклар, саесканнар, карлыгачлар] Барысы да сый өчен сугыштылар, тыпырдаштылар.* Р.Хафизова

3) Мәҗлес, аш, зыяфәт. *[Падишаһ] Борынгы заманнан ук төрмәләрдә онытылып яткан мәхбүсләрне азат итте, бөтен халыкның күңелен яхшылыгы белән шатландырды, күп вакыт сыйлар ясады.* Мәҗмугыл-хикәят. *Гадәттәгечә, тантаналы җыелыштан соң сый мәҗлесе үтте.* Ә.Галиев

4) *күч. ирон.* Җәза, җәбер, күрелгән золым, җәфа. *Ирек даулаганда, Деникин бандаларының сыен татыдым, маңгаема тамга алдым…* Э.Касыймов

◊ **Сыйда йөзү** Сыйлы тормышта яшәү; мул, бай тормыш итү

**СЫЙДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сыю**

2) Берәр нәрсә сыярлык киң, иркен урын булу. *Куе чәчен ак калфагы эченә сыйдырып бетерә алмаган, калфагы эче камыр кебек кабарып тора.* Г.Әпсәләмов. *Дуңгыз салосы бар, печенье уңды, бөтен бригаданы сыйдыра алмасак та, байтак кешене «кунакка» дәштем.* А.Гыйләҗев

3) Берәр нәрсәне урын табып урнаштыру яки берәр җирдән үткәреп җибәрү. *Китапларны букчага сыйдырып бетерү. Зур көзгене ишектән сыйдыра алмау*

4) Берәүне үз янына алу, аңа сыену урыны бирү. *Үги ана баланы янына сыйдырмау*

5) *күч.* Берәр информацияне яисә хис-тойгыларны кабул итү, үзләштерү, урнаштыру. *Мондый вәхшилекне башка сыйдыру мөмкин түгел иде.* С.Зыялы

6) *күч.* Булу, җитү (вакыт тур.). *[Роза:] Вакытың сыйдырса, утырсаң шәп булыр иде.* А.Алиш

7) *күч.* Туры китерү, яраштыру. *Тормыш законнарын ачарга, өйрәнергә, аларны теориядә аерым төшенчәләргә, категорияләргә сыйдыру, берләштерү мөмкин булса да, тәгаен шартларда тормыш үзенчәлекләрен исәпкә алып бетерү мөмкин нәрсә түгел.* Ә.Баян. *Аны тар кысаларга, әзер калыпларга сыйдыруы кыен.* Т.Галиуллин

**Сыйдыра бару** Эзлекле рәвештә, системалы итеп сыйдыру

**Сыйдырып бару** Бер-бер артлы, тәртип белән сыйдыру

**Сыйдырып бетерү** Барысын да сыйдыру. *Романда сурәтләнгән шундый зур үзгәрешләрне дүрт-биш айга сыйдырып бетерү әсәрнең ышандыру көчен бераз киметә.* Р.Зарипова. *Боларның барысын да бер күңелгә сыйдырып бетерү, аңлау, аңлату читен булса да, без бирешмәскә тырыштык.* А.Гыйләҗев

**Сыйдырып тору** Һәрвакыт сыйдыру; бераз вакытка сыйдыру

**СЫЙДЫРЫШ** *и.* 1) Сыйдыру мөмкинлеге; сыйдыру күрсәткече. *Кабан күленең суы ничә чиләк булыр дигәндәй, чиләгемнең сыйдырышы шактый икәнлеген исәпләп, аның сүзләрен тыныч кына тыңлый бирдем.* Ф.Яхин. *Әгәр дә торф аз, ә фекалий җитәрлек булса, бер өлеш торфка 3–5 өлеш фекалий өстиләр (торфның дым сыйдырышына карап).* Йорт эшләре

2) Сукуыш. *Судноның сыйдырышы*

**СЫЙДЫРЫШЛЫ** *с.* 1) Билгеле күләм сыйдыра алырлык, сыйдыра торган. *Әрәмә зурдан булмаса да, бәләкәй отрядны атлары белән бергә сыйды-*

*рышлы иде.* Ж.Рәхимов. *Өч катлы, куәтле, күп пассажир сыйдырышлы чибәр теплоход.* И.Низамов. *Җыенны урданың тышкы ягында, калку үр өстенә корылган йөз кеше сыйдырышлы киез өй эчендә ясадылар.* Н.Фәттах

2) Күп сыйдыра торган, сыйдыру мөмкинлеге зур булган

**СЫЙДЫРЫШЛЫК** *и. к.* **сыйдырышлылык**. *Вагоннарның сыйдырышлыгы*

**СЫЙДЫРЫШЛЫЛЫК** *и.* Сыйдыру, сыйдыра алу мөмкинлеге, дәрәҗәсе. *Ләкин ырымның мәгънәсе, сыйдырышлылыгы моның белән генә чикләнми, ул бер үк вакытта магик характердагы йола-хәрәкәт компонентын да үз эченә ала.* М.Бакиров

**СЫЙЛАНУ** *ф.* Тәмле итеп ашау, эчү һ.б.; сый итеп биргәнне ашау, эчү һ.б. *Февраль аенда гына Садыйк аларда булып, Корбан бәйрәме ашлары белән сыйланып китте.* А.Расих. *Алар ям өендә тупас кына такта өстәл янына утырып сыйланырга тотындылар.* Ж.Рәхимов. *Юныс өендә өч көн сыйландылар.* Г.Шәрипова

**Сыйлана бирү** Һаман сыйлануны дәвам итү

**Сыйлана тору** Берәр хәл булганчы сыйлану

**Сыйланып алу** Тиз генә сыйлану

**Сыйланып йөрү** Һәрвакыт сыйлану

**Сыйланып тору** Даими, регуляр рәвештә сыйлану; хәзер сыйлану

**Сыйланып утыру** Әле, хәзер сыйлану. *Ә без яр буенда ял итеп, сыйланып утырабыз. Әйе, ашап кына түгел, кунактан болай сыйланып!* М.Әмир. *[Аның] Шунда кичен сыйланып утырганда, аларның өлгереп җиткән, бүген үк кияүгә тотып бирерлек матур кызларына күзе төште...* С.Рафиков

**Сыйланып яту** *сөйл.* Сыйлану процессында булу

**СЫЙЛА́П-СЫЙПАП** *рәв.* Җайлап, юмалап; бүләк бирү юлы белән, юмалап (күндерү, риза итү). *Яхшы сүз белән, йомшаклык белән сыйлап-сыйпап, утызлап малайны ияләндергән иде. К.Насыйри*

**СЫЙЛА́П-СЫРЛАП** *рәв. к.* **сыйлап-сыйпап**. *Байлар сыйлап-сырлап үзләренең хайваннарын алып калырлар.* Һ.Такташ

**СЫЙЛА́У** *ф.* 1) Кунак итү, сый тәкъдим итү, ашату, кунакчыллык күрсәтү. *Шәкерт абый миңа май бирә, күмәч бирә, мине сыйлый.* Г.Исхакый. *Ә мин болай дидем: «Юк инде, Михаил, рәхмәт сиңа, гомергә онытмаслык итеп сыйладың син мине. Ашавы да булды, эчүе дә».* Ф.Галиев

2) *күч. ирон.* Җәзалау, кыйнау. *Тормыш аны әче камчысы белән сыйласа, ул аннан чыдамлык, тормышка яраклашу сыйфатлары алган, язмыш киртәләр куйса, үҗәтлеге арткан.* Сәхнә

◊ **Сыйлаганда су эч** Кунак таләпчән булмаска, тыйнак булырга, азга да канәгатьләнергә тиешлеге турында. *Куш учларыма салкын суын алып, Илдарга суздым. Ул эчте-эчте дә: – Сыйлаганда су эч, – дип рәхәтләнеп көлде.* Э.Шәрифуллина

**Сыйлап алу** Бераз сыйлау. *Тоткыннар ишек авызыннан берәм-берәм чигенә башладылар. Эшелон башлыгы --- Мухоморовка боерык бирде: – Башкаларга үрнәк булыр, сыйлап алыгыз бер-икесен!* И.Туктар

**Сыйлап тору** Даими, регуляр рәвештә яки хәзер сыйлау

**Сыйлый башлау** Сыйларга тотыну

**Сыйлый тору** Хәзергә сыйлау; һаман сыйлау

**СЫЙЛАУЧАН** *с.* Кунакчыл, кунак сыйларга ярата торган. *Гайнулла абзый ул – бик кунак сыйлаучан, бик мәрт кеше.* Г.Камал

**СЫЙЛЫ** *с.* 1) Сые булган; сыйлар куелган. *[Гөлсәйдә:] – Алай килешеп бетмәс бит, балалар, – диде. – Еллар күркәм, табыннар сыйлы – нигә гөрләтеп туй итмәскә?* Ф.Яруллин. *Ә кешеләр шуны уйлый микән, Утырганда сыйлы табында?* Х.Җәгъфәр

2) Кунакчыл, килгән кешене сыйларга ярата торган. *Сыйлы хуҗа*

3) Яхшы ашау-эчү белән үтә торган (тормыш тур.). *Сыйлы көнең – сыер белән.* Мәкаль

**СЫЙ-НИГЪМӘТ** *и.* Күп һәм төрле ашамлык-эчемлек. --- *Янчурин аны, терсәгеннән йомшак кына тоткандай итеп, кухняга алып керде, сый-нигъмәттән сыгылып торган өстәл янына утыртты.* Ф.Садриев. *Аннан инде чират табынга җитте, өстәлгә берәм-берәм Гадилә әзерләгән сый-нигъмәт чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**СЫЙНФЫЙ** *с. гар.* 1) Сыйныфлар (*1 мәгъ.*) белән бәйле. *Аның сыйнфый йөзен ачып салып, тиешле чараларны күрәсе урында, хокук сорап биргән заявлениеләрен тикшереп баш ваттылар.* Г.Толымбай. *Ә сыйнфый дошман йоклап ятмый, безне суярга дип, идән астында пычак кайрап ята.* Р.Зәйдулла

2) Берәр сыйныфка, аның идеологиясенә хас. *Сыйнфый караш. Сыйнфый аң*

**СЫЙНФЫЙЛЫК** *и.* 1) Берәр төрле сыйныфның (*1 мәгъ.*) мәнфәгатен яклау үзлеге, бер сыйныфның үзенчәлекләрен чагылдыру. *Гаяз Исхакый нәфасәт өлкәсендә Гафур Коләхмәтовтан соң, мөгаен, беренче булып, сыйнфыйлык проблемасын күтәреп чыга.* К.Гыйззәтов. *Беренчедән, иҗтимагый психологиягә сыйнфыйлык хас.* Философия

2) Сыйныфлардан (*1 мәгъ.*) гыйбарәт булу. *Капиталистик җәмгыятькә сыйнфыйлык хас*

**СЫЙНЫФ** *и. гар.* 1) Иҗтимагый-икътисади дәрәҗәләре, дөньяга карашлары, мәнфәгатьләр уртаклыгы нигезендә берләшкән зур һәм шактый тотрыклы бериш кешеләр төркеме (крестьянлык, урта сыйныф, буржуазия һ.б.ш.). *Эшче сыйныфы, барлык хезмәт ияләре инде күп түзделәр.* А.Расих. *Алар, үзбәк, казах, кыргызларның өстен сыйныф кешеләре белән кулга-кул тотынып, Совет властена каршы җимерү эшләре алып баралар.* С.Шакир

2) Мәктәп курсында бер баскыч; класс. *Бишенче сыйныф баласы язган шигырь осталыгына да ирешкәнең юк!* З.Мәхмүди. *Икенче сыйныфка гына күчкән Самат, бер шигырь язып, --- Мәрьям апасына күрсәткән иде.* Г.Гыйльманов

3) Мәктәптә укучыларның уку елы буенча бүленгән төркеме; класс. *Мәктәпнең дүртенче сыйныфын бетерә торган ун малай, биш кыз, канатлы кошлар кебек, очардай булып йөрибез шул.* Г.Толымбай. *Әлеге вакытта чыгарылыш укучылары өчәр параллель сыйныф тәшкил итә.* Ф.Габидуллина

4) Мәктәптә дәрес укытыла торган бүлмә, дәрес бүлмәсе; класс. *Ишек ачылды, укучылар шаулашканы ургып сыйныфка керде.* Р.Батулла. *Аларны кул сырты белән сыпырып алдым да, кычкырып елап җибәрүдән чак тыелып, сыйныфтан чыгып киттем.* В.Мәҗитова

**СЫЙНЫФЛЫ** *с.* 1) Сыйныфларга (*1 мәгъ.*) аерылган. *Сыйныфлы җәмгыять*

2) Сыйныфы яки сыйныфлары (*2–4 мәгъ.*) булган. *Зәйтүнә, бик нык әзерләнеп, сигез сыйныфлы мәдрәсәнең алтынчы сыйныфына имтихан тота.* М.Гарипов

**СЫЙНЫФЛЫК** *и.* 1) *к.* **сыйнфыйлык**. *Азмы-күпме культура баскычына күтәрелгән хәзерге халыклар общественносында, шул җөмләдән татарларда, сыйныфлык нигезен танымау җирдәге әйберләргә болытлар өстеннән карап фикер йөртүгә охшый.* Ш.Камал

2) Билгеле сыйныфтан (*2–4 мәгъ.*) гыйбарәт; ничәдер еллык. *Җиде сыйныфлык кына белеме булса да, дүрт класс тәмамлап кына укытканнардан ул үзе дә шактый аерылып тора.* Р.Рахман

**СЫЙНЫФСЫЗ** *с.* Сыйныфларга (*1 мәгъ.*) аерылмаган. *Советлар Союзында моңарчы дөнья күрмәгән хәл: сыйныфсыз җәмгыять төзелә.* Р.Фәйзуллин. *Сыйныфсыз җәмгыятькә аяк басучы яңа кеше алдында һәм матди, һәм мәгънәви чиксез киң мөмкинлекләр тора.* К.Гыйззәтов

**СЫЙНЫФСЫЗЛАНУ** *ф.* Үз сыйныфы (*1 мәгъ.*) белән элемтәсен югалтып, башка сыйныфка күчмичә, сыйнфый йөзен югалту; җәмгыять өчен файдасыз кешегә әверелү

**СЫЙНЫФСЫЗЛЫК** *и.* Җәмгыятьтә сыйныфларга аерылмаганлык

**СЫЙНЫФТАШ** *и.* **1.** 1) Бер үк сыйныфтан (*1 мәгъ.*) булган кешеләрнең аерым бер вәкиле

2) Бер сыйныфта (*2 мәгъ.*) укучыларның һәрберсе (бер-берсенә карата); классташ. *Мәүлидә укырга сәләтле, миндә дә дәрт бар. Икенче чиректә яңа сыйныфташларыбызны куып җиттек.* Г.Якупова. *Ә беркөнне ул сыйныфташы Хәмит белән тау итәгенә велосипедта йөрергә чыкты.* Л.Гыймадиева

**2.** *с. мәгъ.* Бер үк сыйныфтан (*1 мәгъ.*) булган. *Сыйныфташ эшче халык яклы булу*

**СЫЙНЫФЧЫЛЫК** *и.* Сыйнфый караштан чыгып кына эш итү күренеше. *Бу кеше – коммунизм идеяләрен примитив аңлаучы вульгар социолог, һәр нәрсәгә сыйныфчылык күзлегеннән генә караучы сәләтсез, сәләтлеләрне күрә алмаучы пароноик.* Р.Батулла

**СЫЙПАЛАНУ** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **сыйпану**. *[Мәдинә], әнкәсенә күрсәтмәскә тырышып, киеменә тиз-тиз генә исле май сеңдерде, көзге алдында туктап сыйпалангандай итте дә, кулына бәйли башлаган оегын-инәсен алып, чыгарга җыенды.* Н.Фәттах

2) Сырпалану; сыенып иркәләнү, назлану. *Тиктормас йомшак бәрхет тавышы белән мыр-р, мыр-р, мыр-р итә, Әсфәннең иягенә сыйпалана.* Г.Сабитов

**Сыйпалана бирү** Бернигә карамый сыйпалану

**Сыйпалана төшү** Бераз сыйпалану

**Сыйпаланып алу** Бераз сыйпалану

**Сыйпаланып йөрү** Бертуктаусыз сыйпалану

**Сыйпаланып тору** Хәзерге вакытта яки гел сыйпалану

**СЫЙПАЛА́У** *ф. кбт. форм. к.* **сыйпау**. *Җәмилнең әткәсе, битләрен бармаклары белән сыйпалап, тамак кырып куйды.* Ф.Нурихан

**Сыйпалап алу** Тиз генә сыйпалау

**Сыйпалап тору** Берникадәр вакыт яки хәзер сыйпалау

**Сыйпалый башлау** Сыйпаларга тотыну. *Сикереп үк атыннан төште, тимеркүкнең нуктасыннан эләктереп алды, тезген очын чишеп җибәрде дә, иплә кенә, иркәләп кенә атның күкрәгеннән, муеныннан сыйпалый башлады.* Ф.Нурихан

**СЫЙПАНУ** *ф.* Чәч, кием, өс-баш һ.б.ш.ны рәтләп-сыйпап төзәтү, үзеңне пөхтәләү. *[Ул] Җиң очларын, яулык читләрен тарткалап куйды. Фатир хуҗасының хатыны да нәкъ шулай сыйпана иде...* Г.Бәширов

**Сыйпана башлау** Сыйпанырга тотыну

**Сыйпана бирү** Бернәрсәгә карамыйча сыйпануны дәвам итү

**Сыйпана төшү** Бераз сыйпану

**Сыйпанып алу** Аз гына сыйпану

**Сыйпанып тору** Хәзер сыйпану; гел сыйпану

**СЫЙПА́П-СЫЙПАП** *рәв.* Йомшак кына, җиңелчә генә кагылып. *Әнисе сатып алган өр-яңа күлмәк һәм мәктәп формасын көн дә бер тапкыр тоткалап, сыйпап-сыйпап карый.* Р.Низамиев

**СЫЙПА́У** *ф.* 1) Йомшак кына сыпыру; шул рәвешчә иркәләү, назлау. *Карт туп-туры ат янына килә, калтыранган ябык кулы белән аны аркасыннан сыйпый, сөя, муеныннан кага.* И.Салахов. *Кемдер хатынның башыннан сыйпады.* А.Расих

2) Йомшак кына, җиңелчә генә кагылып үтү. *Алтынчәч, палатага кереп, караватына утырды да мендәрен сыйпады.* М.Маликова. *Көзге болыннарда сулган чәчәк, юеш җилләр сыйпый талларны.* Р.Әхмәтҗанов

**Сыйпап алу** Бераз сыйпау. *Кыз бәти янына якынрак килде һәм йомшак ак кулы белән аның чем-кара бөдрә йонлы гәүдәсен сыйпап алды.* Р.Низамиев. *Туган ил шундый сагындырган, әлеге чандыр офицерның гимнастёркасын сыйпап алу да тасвир канатына сыймастай ләззәт китерә иде.* М.Әмирханов

**Сыйпап кую** Бер мәртәбә яки әледән-әле сыйпау. *Фәлахның исе китмәде. Шулай да, авылда туып-үскән ир-ат буларак, атның башыннан сыйпап куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Таисия Ивановна ара-тирә улының такыр башыннан сыйпап куя.* М.Насыйбуллин

**Сыйпап тору** Берникадәр вакыт сыйпау; хәзер сыйпау. *– Ихтимал, бик тә ихтимал, – диде ул, буш кулы белән беравык сакалын сыйпап торганнан соң.* С.Сабиров

**Сыйпап чыгу** Рәттән барысын да сыйпау. *Һәммәсенең башыннан сыйпап чыкты, сөйде, елмайды һәм, җылап җибәрмәс өчен, ашыгып ишеккә ташланды.* Ш.Маннур. *Кул аркасын үпте, аннан берәм-берәм бармакларын сыйпап чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**Сыйпый башлау** Сыйпарга тотыну

**Сыйпый бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сыйпау

**СЫЙРАК** *и.* 1) Аякның тездән тубыкка кадәр өлеше; балтыр, чәлтер. *Ләкин табиб: – Алай түгел шул, туганкай, – диде. – Сыйракта ике сөяк, ә ботта бер генә. Гомумән, сыйрак сөяге авыр ялгана.* Ф.Яруллин. *Хатыны чыгып киткәч, Ырсытдин, чыраен сытып, тимер кебек каралган нәзек сыйракларын караваттан салындырып торып утырды.* Я.Зәнкиев

2) *сөйл.* Гомумән аяк. *Ялгыз торна, канатларын җәеп, башын алга сузып, сыйраклары белән озын-озын атлап йөгереп барды да талпынып өскә күтәрелде.* Р.Батулла

◊ **Сыйрак сузу** Үлү, аяк сузу. *Юк, син ашыкмале сыйракларыңны сузарга, аның өчен генә килмәдек әле без чүлләр кичеп, мин барын да онытма әле син, хәшәп!..* Ә.Еники

**СЫЙРАКЛЫ** *с.* Сыйрагы билгеле сыйфатта булган. *Нечкә генә сыйраклы, озын торыклы ап-ак аргамакка атланган зәңгәр чалмалы Әхмәт паша ялгыз казакның бөтен бер гаскәр белән алышуын читтән – тау битләвеннән күзәтеп торды.* М.Кәрим. *Шунда күрәм: пионер галстугыдай кып-кызыл күлмәк, кыршылган джинсы кигән студент яшьләрендәге озын сыйраклы чибәр генә егет дебаркадер янында тана хәтле овчаркасын сатарга ниятләп тора.* А.Хәсәнов

**СЫЙРАТ** *и. гар. к.* **сыйрат күпере**. *Көчем бар дип уйлама, Көчең китәр көн булыр, Янган тәмуг өстеннән сыйрат үтәр көн булыр.* Дастан

◊ **Сыйрат кичү** *к.* **сыйрат күпере кичү**. *Юлымда «Ямանташ» дигән бер тауны үтәсе бар. Хәзерге кебек явым-чәчемле вакытларда бу инде сыйрат кичүдән бер дә ким саналмый.* Г.Ибраһимов

**СЫЙРА́Т КҮПЕРЕ** *и.* 1) Ислам диненә күрә, җәһәннәм уты өстеннән җәннәткә чыгара торган күпер

2) *күч.* Котылу мөмкинлеге икеле булган бик кыен хәл; бик зур сынау, үтә алмаслык киртә

◊ **Сыйрат күпере кичү** 1) Чиктән тыш авыр хәлләрне һәм хәвефле кыенлыкларны үтеп чыгу турында. *[Хаҗи:] Вексельләре сыйрат күпереннән үтә алмый кире чыккач, без аларга икенче төрле бүләк хәзерләрбез, Алла бирсә.* Ш.Мөхәммәдев. *[Солтангалиев:] Кылдан нечкә, кылычтан үткер сыйрат күперләрен кичү җиңел түгел икән, халкым...* Р.Мөхәммәдиев; 2) Авыру кешенең хәтәр кризис үткәрүе. *Сыйрат күперен кичтек, дияргә ярый, туганкай, тереләсез.* Г.Әпсәләмов. *[Врач:] Сез сыйрат күперен кичтегез, артка юл юк сезгә.* С.Сөләйманова

**СЫЙ-РИЗЫК** *и. к.* **сый-нигъмәт**. *Маһинур апаның мул сый-ризыкларыннан өстәл сыгыла иде.* А.Хәсәнов

**СЫЙСЫЗ** *с.* **1.** 1) Сые булмаган. *Сыерсыз кеше – сыйсыз кеше.* Мәкаль. *Бәйрәм сыйсыз булмый, дигән кебек, күгәрченлеләр башкала халкын тәмле ризыклар белән дә сөендерде.* Кызыл таң

2) *күч. диал.* Явым-төшемле, яңгырлы, бозык. *Сыйсыз көн*

**2.** *рәв. мәгъ.* Сыйламыйча, сыйхөрмәт күрсәтмичә. *Кунакларны сыйсыз җибәрмәү*

**СЫЙФАТ** I *и. гар.* 1) *филос.* Предметның, күренешнең, процессның иң әһәмиятле билгеләрен, үзенчәлекләрен эченә алган төп асылы. *Сыйфат үзгәрешләре кичерү. Микъдарның сыйфатка күчүе*

2) Үзлек, билге, аерымлык. *Мактану, әлбәттә, бер караганда әйбәт гадәт саналмый. Шулай да минем ул гөнаһсыз сыйфатны байларга гына биреп бетерәсем килми.* М.Әмир. *Бөркет күзе, кешенеке белән чагыштырганда, ерактанрак күрә, әмма кеше күзе әйбернең төрле сыйфатын бөркетнекеннән күбрәк аера ала.* М.Насыйбуллин

3) Берәр нәрсәнең яхшылык, кыйммәтлелек, яраклылык дәрәҗәсе, таләпләргә җавап бирүчәнлек. *Сыйфат комиссиясе председателе чәчү чорында кырга аяк басмады.* М.Хәбибуллин. *Республика терлекчеләре ит, сөт һәм башка продуктлар җитештерүне арттыра бару белән бергә аларның сыйфатын яхшырту чараларын да күрәләр.* Татарстанда терлекчелек

4) Килеш-килбәт, кыяфәт, тышкы күренеш. *Өс-башын калача кәчтүм һәм ботинкаларга алыштырган, алтын сәгатен таккан, кулына тимер таяк алган сыйфатта, иярләнгән сыер хәлендәрәк булуыннан котылырга теләп, ике генә кәлимә әйтте: – Мәрхабә, туганкайлар...* Ф.Яхин

**СЫЙФАТ** II *и. гар. лингв.* **1.** Предметның билгесен белдерә торган сүз төркеме. *Сыйфатлар рәвешләрне күбрәк янәшә тору чарасы һәм лексик мәгънә аркылы ияртәләр.* М.Зәкиев

**2.** *с. мәгъ.* Шул сүз төркеме функциясен үти торган. *Сыйфат сүз*

**СЫЙФАТЛАМА** *и.* Тасвирлама, характеристика, сыйфатлау бәяләмәсе. *Югарыда әйтелгәнчә, без халык җырларын дүрт төркемгә бүлгән классификациягә таянабыз һәм алга таба, һәр төргә кыскача сыйфатлама биреп, аларның төп үзенчәлекләрен яктыртуны күздә тотабыз.* К.Миңнуллин. *Корылманы хисаплау алдыннан андагы элементларның геометрик үлчәмнәре һәм формалары, ул эшләнгән материалның физик сыйфатламалары, тышкы йөкләмнәр һәм аларның тәэсир итү үзенчәлекләре билгеләнә.* Корылма механикасы

**СЫЙФАТЛАНМЫШ** *и. лингв.* Җөмләдә яки сүз тезмәсендә сыйфат (II) белән ачыкланып, билгеләнеп килгән сүз. *Сыйфат һәм сыйфатланмыштан гыйбарәт тәгъбир*

**СЫЙФАТЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **сыйфатлау**. *Бу чор түбәндәгечә сыйфатлана*

**СЫЙФАТЛА́У** *ф.* 1) Характерлау, тасвирлау; бәяләү. *Рецензент, гомумән алганда, әсәрне бик уңай бәяләсә дә, әсәрдәге төп персонажларның берсе булган Давыт Урмановның образын сыйфатлаудагы кимчелекләргә аеруча басым ясаган иде.* Г.Мөхәммәдева. *Җәйсур бер озын өйнең буенча келәм тукыды, бизәк урынына күфи язуы белән үзенең хәлен сыйфатлап язды, бик яхшылап, җиренә җиткереп тәмам иткәч, яһүдкә бирде.* Мәҗмугыл-хикәят

2) Күрсәтү, чагылдыру, гәүдәләндерү. *Табигать күренешләрен сыйфатлау*

**Сыйфатлый бару** Һәммәсен тоташтан сыйфатлау

**Сыйфатлый башлау** Сыйфатларга тотыну

**Сыйфатлап алу** Тиз генә сыйфатлау

**Сыйфатлап тору** Даими яки регуляр рәвештә сыйфатлау

**Сыйфатлап чыгу** Баштан ахырга кадәр, рәттән сыйфатлау

**СЫЙФАТЛАШУ** *ф. лингв.* Башка сүз төркемнәреннән сыйфатка (II) әйләнү, күчү

**СЫЙФАТЛЫ** *с.* **1.** 1) Билгеле сыйфатка ия. *Югары сыйфатлы корыч, сабы да агач түгел – бәрелү-сугылуга чыдам пластмасса...* А.Тимергалин. *Төньяк Америка белән Көнбатыш Аурупадан Русиягә агылучы азык-төлек, тәмәке һәм эчемлекнең – 80 проценты, ә даруларның хәтта 90 проценты начар сыйфатлы.* Татар мөселман календаре

2) Яхшы, әйбәт, кыйммәтле. *Бораунын дөрес сайланып дөрес файдаланылуы – сыйфатлы скважина бирүнең нигезе.* М.Хәсәнов. *Әмма ләкин иртә таңнан алып караңгы төнгә кадәр өчләтә, хәтта бишләтә эшләячәкләренә, сыйфатлы итеп эшләячәкләренә: бер җәйдә бер дигән мактап өлгертәчәкләренә иманым камил.* Ж.Дәрзаман

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиешле итеп, таләпләргә туры китереп. *Язгы кыр эшләрен кыска вакытта һәм сыйфатлы башкарып чыгу өчен, иң беренче чиратта, югары җитештерүчәнле техника таләп ителә.* Кызыл таң

**СЫЙФАТЛЫЛЫК** *и.* 1) Сыйфатлы булу дәрәҗәсе. *Орлыкның сыйфатлылыгын билгеләү. Продукциянең сыйфатлылыгын күтәрү*

2) Югары сыйфат. *Сыйфатлылыгы күренеп тора*

**СЫЙФАТСЫЗ** *с.* **1.** Начар сыйфатлы, яраксыз, тиешле таләпләргә җавап бирми торган. *Моның ике сәбәбе бар. Беренчедән, су эчендә маташалар, икенчедән, сыйфатсыз, ягъни бракланган скважиналарны төзәтеп йөриләр.* К.Кәримов. *Хәзер товары да сыйфатсыз бит аның. Бер генә киярга, ямасаң да файдасы юк.* Р.Габделхакова. *[Рәүф:] Нииндидер сыйфатсыз бензин кузне боза дип ишеткәнем бар.* Г.Зәйнашева

**2.** *рәв. мәгъ.* Начар, түбән сыйфатлы итеп. *Сыйфатсыз эшләнгән йорт җиһазы өчен дә җаваплы кешене табып була.* Р.Батулла

**СЫЙФАТСЫЗЛЫК** *и.* Яраксызлык, түбән сыйфат. *Эшләнмәнең сыйфатсызлыгы*

**СЫЙФА́Т ФИГЫЛЬ** *и. лингв.* Үзендә фигыль һәм сыйфат сүз төркемнәренең билгеләрен берләштергән затланышсыз фигыль формасы. *Семантик яктан сыйфат фигыльләрдә, башка фигыль формаларындагы кебек ук, эш-хәл, процесс мәгънәсе белдерелә.* Татар грамматикасы

**СЫЙФАТЫНДА** *бәйл. кит.* «Итеп», «буларак» мәгънәләрен белдерә; шундый кеше буларак. *Хәлбуки, вәкил сыйфатында Казанга килгән Яков Свердлов, әле егерменче яшендә генә булса да, җитлеккән профессиональ революционер иде инде.* А.Расих. *Икесен дә, сугышка китүчеләр сыйфатында, күршетирә җыйнаулашып, күзләр сөрткәләп, кул болгап озатып калдылар.* Ә.Баян. *Акушерканы алып, Гыйльфан шофёр сыйфатында бара.* С.Сөләйманова

**СЫЙ-ХӨРМӘТ** *и.* 1) Затлы ашамлык-эчемлекләр куеп күрсәтелгән кунакчыллык. *Бер бүлмәдә җыр-бию, күңел ачу барса, икенче бүлмәдәге аш өстәле тирәсендә сый-хөрмәт кызды.* Я.Зәнкиев. *Булмаган ризыкларын чыгарып, аларны сый-хөрмәт иттеләр.* Н.Сәфәрев

2) Мул тормыш. *Сый-хөрмәттә яшәү*

3) Зурлау, олылау; мактау, ихтирам, хөрмәт. *Кыскасы, мөсафирга сый-хөрмәт күрсәтүдән, садака бирүдән бирәүгә дә зыян килми, Аллаһы Тәгалә аларны артыгы белән кайтарачак.* Мөселман гаиләсе календаре

**СЫККЫЧ** *и.* Үсемлек орлыкларыннан май сыгып алу әсбабы. *Сыккыч белән киндер орлыгының маен чыгару*

**СЫКРА** *с. диал.* **1.** 1) Бәвелне тота алмаучы. *Сыкра малай*

2) *күч.* Мыгырдаучан, сукранучан, мыгырдавык

3) *күч.* Саран, карун. *Сыкра кеше*

**2.** *и. мәгъ. мед.* Бәвелне тота алмау авыруы. *Сыкра белән авыру*

**СЫКРАНУ** *ф.* 1) Җиңелчә ыңгырашу, иңрәү. *Учлар сыдырылып канап, бармак башларының тиресе кубып, төннәр буе сыкранып, җыламсырап ята торган идек...* А.Гыйләҗев. *Сыкранып җиргә ауган солдатлар, актык көчләрен җыеп, дөнья белән бәхилләшә...* Н.Хәсәнов

2) Кайгырып зарлану, уфтану. *– Катырма түгел, нан ашыйсым килә! – дип сыкранды энем.* Н.Сәфәрев

3) Еламсырау, борчылып яшь түгү. *Олы гына яшьтәге бер хатын шуңа тәэсирләнеп: – Җитәр, кызым. Бу җырың бигрәк авыр икән, – диде, яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп алды. – Бирегә без сыкранырга түгел, күңел ачарга дип килдек.* Н.Сәфәрев. *Әнә картлар аның каршында елыйлар, сыкраналар.* Н.Дәүли

4) *күч.* Елауга, иңрәүгә охшаш тавышлар чыгару. *Урамда атлар кешни, сыерлар мөгри, сарыклар бәэлди, һәм тәгәрмәчләрнең сыкранып шыгырдаганы ишетелә.* Н.Сәфәрев. *Ул баскан саен сыгылып куйган өйалды идәне суыктан сыкранып-сыкранып калды.* Р.Мөхәммәдиев

5) Рухи газап кичерү, йөрәк әрнү. *Бәлки, ул, гомере буе үзенең шул сыйфатыннан рухи газап кичереп, сыкранып, җәфаланып яшәгәндер?* М.Мәһдиев

**Сыкрана бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сыкрану

**Сыкрана төшү** Бераз сыкрану

**Сыкранып алу** Берара сыкрану

**Сыкранып йөрү** Даими сыкрану

**Сыкранып кую** Бер мәртәбә сыкрану. *Ул йөрәге авырткандай сыкранып куйды, ләкин күңелендәге шигенә алай җиңел генә үсеп китәргә юл бирәсе килмәде.* Г.Бәширов

**Сыкранып тору** Даими яки регуляр рәвештә сыкрану

**Сыкранып утыру** Әле, хәзер сыкрану

**СЫКРАНУЛЫ** *с.* Сыкрану катыш, сыкрануны белдергән. *Шуның тасма кебек юка җепселләре, җил искәндә, нииндидер әрнүле ыңгырашуга да, сыкранулы моңга да охшаш аваз чыгарып торалар.* З.Фәйзи. *Ә бүгенге аяныч хәләт үз халкын яраткан язучы өчен шаяртып көлү дә, мыскыллап көлү дә була алмый: бары тик әрнүле, сыкранулы көлү генә!* А.Әхмәдуллин

**СЫКРАНУЧАН** *с.* Һәрвакыт зарланучы, канәгатьсезлек белдерүче; сукранучан. *Крестьян кешесе – болай да сыкранучан, зарланучан халык.* Г.Бәширов

**СЫКРА́П-СЫКТАП** *рәв.* 1) Ыңгырашып, аһ-ваһ килеп

2) Ялварып, күз яшьләре белән ялынып. *Дөресен әйтергә кирәк, Фатыйма карчык Гөлчәчәкне сыкрап-сыктап кына алып калды.* Ф.Яруллин

**СЫКРАТКЫЧ** *с.* Зарланырга, сыкранырга мәҗбүр иткән. *Күңелне сыкраткыч чыңбарлык*

**СЫКРА́У** I *ф.* 1) *к.* **сыкрану** (*1 мәгъ.*). *Кулның әрнүенә чыдый алмыйча сыкрап елау*

2) Авырту, сызлау, әрнү. *Яраларым сызлый башлады. Тән сыкрый, кәеф яман.* Р.Батулла

3) *күч.* Кайгырып борчылу, хәсрәтләнү; күңел сызлану, тынычсызлану. *Бу җырларны ишеткәч, күңел тула, йөрәк әрни һәм сыкрый, сызланасың һәм тирән уйга чумасың!* М.Латыйфуллин. *[Мөхлисә карчык] Әчтән нык сыкрап булса да, киявенә хәер-фатихасын бирде.* Я.Зәнкиев

**Сыкрап алу** Берара сыкрау

**Сыкрап йөрү** Һәрвакыт сыкрау

**Сыкрап кую** Бер мәртәбә сыкрау. *Аның да кинәт йөрәге әрнеп, сыкрап куйды.* М.Хәсәнов. *Ананың йөрәге сыкрап куйды.* Р.Хафизова

**Сыкрап тору** Өзлексез сыкрау

**Сыкрый башлау** Сыкрарга тотыну

**СЫКРА́У** II *и.* Сагыш, күңел төшенкелеге. *Аны моң, сагыш, сыкрау баскан.* А.Хәсәнов. *Болытлардан бозлар яуганда да Юк күңелдә сыкрау, Юк әрнеш.* Ә.Исхаков

**СЫКРЫ́Й-СЫКРЫЙ** *рәв. к.* **сыкрап-сыктап**. *Башта Шәйхи дөнья күргән тәҗрибәле карт солдатларның сыкрый-сыкрый тәкъдиргә буйсынып, исән калуны өметләнеп яши алуларына гаҗәпсенде.* И.Туктар. *Шул көнне тагын бер җан әрнеткеч нәрсәгә туры килдем. Табак бит белән бәхәсләшкәннән соң сыкрый-сыкрый кайтып киләм, чак атлыйм.* А.Шамов

**СЫКТАК** *с. диал.* **1.** Елак, күп сыкрый торган. *Сыктак карчык*

**2.** *и. мәгъ.* Елак, елак кеше. *Ул сыктак түгел*

**СЫКТАНУ** *ф. диал. к.* **сыкрану**. *Шул мәлдә авыр итеп ыңгырашып, сыктанып куйган Сәет коткарды аны.* Т.Галиуллин

**СЫКТА́У** *ф. к.* **сыкрау** (*1, 3 мәгъ.*). *Ай, ул җанның яшертен генә сызланып сыктаулары, тән гайрәтен басарга теләп уфылдаулары!* Ә.Гаффар. *Тол хатыннар иң авыр елларда да сыгылмадылар, сыктамадылар.* И.Низамов. *Моңланып та арыдым, сыктап та арыдым, елмаерга иде миңа, елмаерга иде...* Н.Гыйматдинова

**Сыктап алу** Бераз сыктау

**Сыктап җибәрү** Кинәт сыктарга тотыну

**Сыктап кую** Бер мәртәбә сыктау. *Мәрзияне күргәч, Шәүкәт түзмәде, сыктап та куйды, кат-кат чын йөрәгеннән чыккан рәхмәтләрен укыды.* Я.Зәнкиев

**Сыктап тору** Өзлексез сыктау

**Сыктый башлау** Сыктарга тотыну

**Сыктый бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сыктау

**Сыктый төшү** Бераз сыктау

**СЫКТАШ** *и.* Сулкылдау, елау, елау-сыктау күренеше. *Бөтен җирдә елаш та сыкташ*

**СЫКЫ** *и.* 1) Әйбер өстендә аның үз парыннан хасил булган юка гына кар катламы. *Урамга чыктык. Куе булып сыкы төшкән.* М.Хәсәнов. *Айлы кич иде. Җиргә салкын сыкы иңде.* Ф.Яхин. *Сыкы нечкә ботакларга һәм телефон чыбыкларына кунмый.* Дөньяда ниләр бар

2) Кышкы салкында сыек томан булып кына җемелдәп күренә торган кар бөртекләре. *Кояш, гүя салкын сыкы белән капланган, сүрәнәеп, урман артына төшеп бара.* М.Галиев. *Ә тышта җил тынып калган, чалт аяз күк йөзенә эре йолдызлар сибелгән, аларның кыйпылчыгы кебек, урам баганаларындагы утлар яктысында җемелдәп сыкы коела иде.* М.Маликова

**СЫКЫЛАНУ** I *ф.* Сыкы белән каплану

**Сыкылана төшү** Беркадәр, бераз сыкылану

**Сыкыланып бетү** Тәмам, нык сыкылану

**СЫКЫЛАНУ** II *и.* Сыкы белән каплану күренеше. *Бу салкынайган тигез җирләргә туңган чык тамчыларына охшаган вак боз шарчыклары утыра. Менә бу күренеш сыкылану дип атала.* Дөньяда ниләр бар

**СЫКЫЛА́У** *ф.* 1) Сыкы белән каплану

2) Сыкы барлыкка килү, сыкы күренү. *Һава сыкылаган*

**СЫКЫЛЫ** *с.* Сыкы белән капланган. *Әле шул чукракландырырга маташкан ерак сахралардан борылып кайткач та җәйге җылы яңгыр шавын ишетеп, урманнарны урталай ярып, сыкылы чаналарның ак карны сөреп җырлап үтүләрен тыңлап бер генә кинәнмәдем.* А.Гыйләҗев. *Ялкау таң ниһаять атты. Уңда-сулда басу сакчылары – сыкылы ялгыз агачлар калды.* Я.Зәнкиев. *Бәсләнгән сыкылы агачлар, йорт-каралтылар, телеграм баганалары артка йөгерә.* Р.Мулланурова

**СЫЛ** *и. диал.* 1) Кайнап чыккан колмак суына он болгатып ясалган, камыр изү өчен махсус әзерләнгән сыекча

2) Көрпәне суга салып ачыту юлы белән ясалган чүпрә

**СЫЛА** *и. зоол.* Алабуга балыклар семьялыгыннан күбрәк агым суларда яши торган балык; судак. *Севан күленнән китерелгән форель, Байкал омуле, Каспий сыласы, төньяктан китерелгән ала балык яңа шартларга күнегеп китәләр.* А.Муранов

**СЫЛАВЫЧ** *и. этн.* Хатын-кызның чәч толымнарын эчкә җыеп киелә торган баш киеме

**СЫЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сылау** I (*1–3, 7 мәгъ.*). *Чолганышта калган иптәшләре барлы-юклы патроннарының соңгысына хәтле сугышып кан койганда, Айсетдин немец шпигы мул сыланган ак күмәчне мүкелдәтеп утыра иде.* Я.Зәнкиев

2) Ябышу, йогып калу, эләгү. *Җир дә, беленер-беленмәс кенә сузылып яткан юл да кибеп җитмәгән, пычрак иде әле, авыр туфрак аякларга сылана иде.* А.Шамов. *Кызыл балчык тирәнгә төшкәч тә каты токымнардан исәпләнми, ләкин ул долотоның тешле тәгәрмәчләренә сыланып, аяк чолгавы*

*сыман урала һәм тиз бораууларга ирек бирми.* К.Кәримов

3) *сөйл. хуплм.* Килешсез, ямьсез итеп косметиканы сөртү, артык калын итеп ягу. *Сыланып кына матур булып булмый*

4) Кием гәүдәнең һәр җиренә тиеп, тыгыз ятып тору, иркен булмау. *Дания өстендә алсу төстәге юбка, тәненә сыланып торган ак свитер кигән, йөгергәндә, каймак кебек аксыл балтырлары елт-елт итә.* М.Хәбибуллин

5) *күч.* Нәрсәгә дә булса елышып урнашу, тиеп тору. *Кыз бөтен гәүдәсе белән тәрәзәгә килеп сыланган иде.* Ф.Хөсни

6) *күч.* Күп булып ябырылу, сырып алу. *Кәҗә бакыруына, урамда туп тибүче бер төркем малай-шалай, уеннарын ташлап, Гайзулланың капкасына килеп сыландылар.* М.Хәбибуллин

7) *күч.* Әрсезләнеп, тыйнаксызлык күрсәтеп, кемгә дә булса сыену, елышу, кочагына керү. *Җанашым бөтен тәне белән миңа сыланды.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Кемгә дә булса әрсезләнеп ияpү, яныннан китмәү. *Егетләрнең китәсе килми, сагыз шикелле сыланырга маташалар.* Ш.Маннур. *Акча хәл итә бу дөньяда һәрнәрсәне: кесәңдә кыштырдап торса, хатыны да сылана, хуҗалар да аяк астында бутала.* Т.Галиуллин

**Сылана бару** Торган саен ныграк сылану

**Сылана башлау** Сыланырга тотыну

**Сылана бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сылану

**Сылана төшү** Бераз сылану; тагын сылану

**Сыланып алу** Берара, тиз генә сылану. *Динә, шаяргандай итеп, Кифаяне читкәрәк тартты, аның киң итеп тегелгән җиңсез юка күлмәге тартылып, сынына сыланып алды.* М.Маликова

**Сыланып бетү** Бөтенләй, тәмам сылану. *Бүлмәнең бер почмагында шәйләнгән ут ничек кенә зәгыйфь янмасын, Рәмзия барыбер күреп торды: кызлар егетләрнең кочагына кереп, тәмам сыланып бетеп биилә́р, муеннарына сарылалар, бер-берсенең чәчләренә күмелеп әйләнәләр иде.* С.Шәмси

**Сыланып калу** Нindидер вакыйгадан, тәэсирдән соң сылану. *Ул көнне кечкенә сабыйлар да әниләренә ияреп килә: май язгач, чүлмәккә сыланып калган сөт өстен бармаклары белән ялыйлар, май әйрәне эчәләр.* Р.Хәбибуллина. *Өсләребезгә сыланып калган киемнәрдән шабырдап су ага.* Р.Рахман

**Сыланып тору** Гел сылану; хәзер сыланган булу. *Ул тигез, кайнар сулыш ала, күлмәге сыланып торган йомры күкрәге еш-еш күтәрелеп куя, күз кашлары моңсулана, кызның күңелендә моңарчы булмаган бер тантана канат җәя иде.* С.Рафиков. *[Айсетдиннең] Гимнастёркасы таза гәүдәсенә ятып-сыланып тора, хром итегенең кунычлары кояшта елык-ялык килә ---.* Я.Зәнкиев

**СЫЛАНУЧАН** *с. к.* **сыланчык**. *Өстәвенә күл төбе баткакланды, аяклар сумала шикелле сыланучан ләмгә ябыша башладылар.* Г.Әпсәләмов. *Сыланучан җепшек кар машинаны сырып бетергән.* Ватаным Татарстан

**СЫЛАНУЧАНЛЫК** *и.* Сыланучан булу

**СЫЛАНЧЫК** *с. сөйл.* 1) Ябышып ияpә, сылана торган. *Сәгать өчләрдә үк шәһәрне күшектергеч, сыланчык, салкын томан каплады.* М.Маликова. *Сыланчык балчык*

2) *күч.* Әрсезлек, әдәпсезлек күрсәтеп, берәүгә елышучы, ияреп йөрүче. *Сыланчык хатын*

**СЫЛА́П-СЫЙПАП** *рәв.* 1) *к.* **сыйлап-сыйпап**

2) Иркәләп сыйпап, йомшак кына кагылып. *Аны өф итеп, сылап-сыйпап кына бердәнбер шкаф эченә элеп куйды.* Д.Булатова. *Алар бәби мунчасында күпме хатын-кызларны сылап-сыйпап сәламәтлекләрен ныгытты.* Безнең гәҗит

3) Җиңел чаралар күреп кенә; ныгытып дәваланмыйча. *Бу зәңгелә дигәннәрен сылап-сыйпап кына җиңеп булмый.* Г.Сабитов

4) Карап, саклап, игътибар итеп. *Үзеңне үзең сылап-сыйпап йөрмәсәң, авыруың бик тиз буласы.* Г.Камал

**СЫЛА́ТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **сылау**

**СЫЛА́У** I *ф.* **1.** 1) Ябышып калырлык итеп йоктыру; ягу, сөртү. *Юкарак кына җәйгән камыр йөзенә орлыкны төеп, сөт белән туглап сылаган, мичтә пешереп алган.* Х.Камалов. *Икмәк өстенә май сылау. Цемент сылау*

2) Берәр үзле нәрсә белән тоташтан каплау (стена, мич һ.б.ш.ларны). *Кояш баешка таба киткәч кенә, Хәнифә мунча сыларга керешә.* М.Хәбибуллин

3) Тишек-ярыкларны берәр үзле нәрсә белән ябышып калырлык итеп томалап каплау. *Кызлар кулларыннан килгәнчә мактәпне әз-мәз караштырып, мич-морҗаларын төзәткәләп, ярыкларын сылап агарттылар.* Я.Зәнкиев

4) Бизәнү, дәвалау һ.б.ш. максатлары белән крем, май, бал, мазь һ.б.ш.ны ягу. *Агач согын сөялләргә, лишай һәм авырткан сеңерләргә сылыйлар.* Мөселман гаиләсе календаре. *Тәнеңә бераз тоз, чәй содасы кушылган бал сылау да файдалы.* Кызлар энциклопедиясе

5) Дәвалау максаты белән тәннең авырткан, сызлаган җирен уу, ышку; массаж ясау. *Мөхлисә әби, кыска-кыска гына аңлатып, Мөхәммәт белән Санияне таныштырды, чоланнан аю мае алып кереп, Саниянең аягын сыларга җыена башлады.* Я.Зәнкиев. *Беркайда укымаган, кроликлар, этләр өстендә бернинди практика үтмәгән, рус телен белмәве аркасында томана дип аталган авыл карчыгы дөп-дөрес итеп кеше организмындагы кан йөреше юнәлешен белгән, кайсы уңайга сыларга кирәген өйрәнгән.* Э.Шәрифуллина

6) *күч.* Үзенең карамагында булган яраксыз, начар нәрсәдән арыну-котылу максаты белән берәүгә сатып җибәрү яисә башка нәрсәгә алыштыру. *Ярамаган киемне берәрсенә сыларга тырышу*

7) *күч.* Бәрү, тондыру, кундыру, чәпәү. *Хәзер шушы шомлы төенне, шушы элмәкне Сәгъдетдингә сыларга дип, бер-берсен уза-уза урам уртасыннан баралар.* Я.Зәнкиев

8) *күч.* Килешсез, ямьсез яки тиешеннән артык итеп сөртү, бизәнү, йоктыру. *Биткә иннек сылау*

9) *күч.* Нindидер эшне, гаепне кемгә дә булса сылтау, кайтарып калдыру, тагу. *[Серебряный:] Яу чыгарга фатиханы Макарий атакай үзе бирде. Гаепне аңа сыламакчымы әллә син?* М.Маликова

**Сылап алу** Тиз генә, бер тапкыр сылау

**Сылап ату** Тиз арада сылау

**Сылап бару** Рәттән, бер-бер артлы сылау

**Сылап бетерү** Бөтенесен сылау

**Сылап җибәрү** Тиз генә сылау. *[Гайшә (кесәсеннән иннек чыгара):] Иң шәбе бар. Үземә генә дип алган идем. Бәясе дә арзан гына: өч сум. Мә, шуны сылап җибәр әле. 75 яшьлек әбиеңнән 18 яшьлек кыз ясый да куя.* В.Нуриев

**Сылап кую** Сылап, әзер хәлгә китерү; алдан сылау; тиз генә сылау. *Ә Уйнак алданды: сыйны ерактан гына иснәп карамакчы булган иде, малай җаен туры китереп, бер кап «Имбирь»не аның битенә сылап куймасынмы!* М.Маликова. *Тиздән укытуларың башлана, шул мунчаны сылап куйсаң икән.* М.Хәбибуллин

**Сылап тору** Даими яки регуляр рәвештә сылау

**Сылап чыгу** Һәр яктан һәм булган берсен сылау

**Сылый башлау** Сыларга тотыну

**Сылый бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сылау

**Сылый тору** Берәр эш-хәлгә кадәр сылау

**Сылый төшү** Тагын бераз сылау

**СЫЛА́У** II *и.* 1) Сылау эше. *Чүпрәкләр белән тыккалау, сумала белән сылаулар да күп файда бирми башлаган иде.* Ш.Камал

2) Ярык-тишекләрне, стенаны һ.б.ш. томалап каплау өчен кулланыла торган махсус масса. *Аларның да сылаулары, мичнеке кебек үк искереп, катып беткән иде.* Г.Гобәй

**СЫЛАУЧЫ** *и.* 1) Массаж ясаучы; шул эшнең белгече

2) Цемент, измә, известь, шпаклёвка һ.б.ш.ны стенага ябыштыру, йоктыру, ягучы белгеч. *Смена бетәргә шактый вакыт бар иде әле, бригадир Людмила апалары аларны нинди эшкә кушар икән: спорт залындагы измә сылаучыларга булышмага җибәрерме, әллә кафе-бар дигәненә бүгеннән үк бизәү төшерә башларга диярме?* Э.Касыймов. *Урта мәктәпне тәмамлаганда, балалар ташчы, балта остасы, сылаучы яки буяучы таныклыгы алып чыгалар.* Э.Шәрифуллина

**СЫЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **сылау**. *Мичне сылашу*

2) *ялг. к.* **сылану** (*2 мәгъ.*). *Күмер тузаны, тиргә сылашып, шахтёрларны моржа әрчүчеләр кебек ясый.* А.Алиш. *Алар [төерчекләр] кан системасының нәзек капиллярлары эчлегенә сылаша, купмаслык булып кан юллары эченә утыра.* Мөселман гаиләсе календаре

**СЫЛТАМА** *и.* 1) Төп тексттагы язуның, өземтәнең яки башка мәгълүматның чыганагын күрсәтә торган язма. *Шагыйрь урыны белән Тукай әсәрләренә сылтамалар да ясый ---.* Х.Миңнегулов

2) *информ.* Билгеле мәгълүматны күрсәтә, ләкин аны сакламый торган объект

**СЫЛТА́У** I *ф.* 1) Җинаять, гаеп, начар эш һ.б.ш.ны берәү эшләгән дип күрсәтү, шуңа тагу. *Баштарак бу хәлне рекрутларга сылтаганнар.* К.Нәҗми. *Әмма никадәр генә атка сылтасам да, күңелнең бер төше үземнең дә гаеп барлыгын сиздереп тора.* Г.Бәширов. *Аларга малның хуҗасыз булуы кулай: соңыннан бөтен гаепне юлбасарларга сылтыйсың да – вәссәлам.* З.Фәтхетдинов

2) Нинди дә булса җитешсезлекне яки кимчелекне берәр сәбәпкә кайтарып калдыру. *Болар өчен гаепне инде үзе үк заманга сылтый.* Р.Рахман. *Берәүләр барысын да акчага, укытучыларның хезмәт хакы түбән булуга сылтап калдырса, икенчеләр гаепне студентларның үзләреннән эзләргә тырыша.* Ватаным Татарстан

**Сылтап бару** Эзлекле рәвештә сылтау

**Сылтап килү** Электән үк, эзлекле рәвештә сылтау

**Сылтап кую** Тиз генә сылтау. *– Кит шушыларны, әллә ниләр уйлап торалар, – дип, безгә сылтап куйды, җитмәсә, үзенең мәзәген.* Г.Якупова. *Әгәр дә Гүзәл баланы берәр нәрсә эшләтеп үтерә калса, күр дә тор, аңа сылтап куячак.* З.Кадыйрова

**Сылтап тору** Даими, әледән-әле яки хәзер сылтау

**Сылтый башлау** Сылтарга тотыну

**Сылтый бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сылтау

**СЫЛТА́У** II *и.* Аклану, бәйләнү, һөҗүм итү һ.б.ш. өчен китерелә торган нигезсез сәбәп. *Сезгә укол кадатырга бөтен Париж егетләре йөри башлаячак. Кирәксә дә, танышу өчен сылтау, хәйлә белән дә.* А.Хәсәнов. *Әйе, берәр сылтау табып сугыш башларга кирәк.* Т.Миңнуллин

**СЫЛУ** *с.* **1.** Матур, нәфис, гүзәл, чибәр. *Бала үзе төскә сылу, эшкә кыю була.* И.Салахов. *Кенәзбикә тәмам өлгереп, өзелеп җиргә төшкән алмадай сылу иде.* М.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ.* Матур кыз. *Сылулар бит санаулы гына була, булганнарының да озатып йөргән егетләре бар.* Р.Мөхәммәдиев

**СЫЛУЛАНУ** *ф.* Матурлану, чибәрләнү, сылуга әйләнү. *Фәния үзе белән бергә укыган, ләкин әллә ни арада шул тиклем сылуланып өлгергән кызга карап җыру әйтә ---.* Ф.Яруллин. *Марфа диңгездән тагы да сылуланып, тагы да назлыланып кайткан иде.* М.Мәһдиев

**Сылулана бару** Торган саен ныграк сылулану

**Сылулана башлау** Сылулануга таба үзгәрү

**Сылулана төшү** Бераз сылулану; тагы да сылулану. *Син, гүзәл бикәм, үзгәрмәгәнсең дә кебек, ә тагын да сылулана төшкәнсең.* М.Хәбибуллин

**Сылуланып калу** Берәр вакыйгадан соң сылулану

**Сылуланып килү** Соңгы арада сылулану

**Сылуланып китү** Тиз арада шактый сылулану. *Чәчәкле күлмәк өстеннән ак алъяпкыч бәйләгәч, Раузаның болай да зифа сыны тагын да сылуланып киткән.* И.Низамов. *Ул үзгәргән: битләре тулыланып, сылуланып киткән, элеккеге үзенә тарта торган битараф, мөлаем карашына ниндидер ачыклык, кызыксынучанлык төсе кергән шикелле.* Х.Камалов

**СЫЛУЛЫК** *и.* Матурлык, нәфислек, чибәрлек. *Сорыйсы иде бер: үзенең шушы сылулыгын белә микән ул?* В.Нуруллин. *Аның [Зәйтүнәнең] өстендә йөнтәс тукымадан тегелгән буйлы халат, киң җиңе эченнән куллары терсәккә кадәр чыгып тора, озын*

*билбау гәүдәсенең сылулыгын күрсәтә иде.* М.Маликова

**СЫМАК** *бәйл. к.* **сыман**. *Шактый гомер үтеп тә, чибәрлеген, күркәмлеген югалтмаган, авыл хатыннары сымак вакытыннан элек картаерга, олыгаерга өлгермәгән, яшь булып кала торган Зәйнәпне күргәч, --- Маһруза бер мәлгә каушап калды.* Х.Ибраһим. *Тегермәнче Галәветдин сымак комнан бау ишмә.* Ә.Гаффар. *Мин гаепсез кеше сымак турсаеп басып тордым.* Н.Сәфәрев

**СЫМАН** *бәйл.* Кебек, күк, шикелле, төсле. *Ул миңа ерактан ук ничектер таныш сыман тоелды.* С.Сабиров. *Бозлы миләшләр сыман чекерәеп, күктә әле һаман төнге йолдызлар яна иде.* Р.Низамиев. *Рәшидә – бер ишкәккә, Уразаев икенчесенә тотынып, көймәне баягы сыман борыны белән ярга борырга тырыштылар.* Я.Зәнкиев

**-СЫМАН** Кайбер кушма сүзләрнең «шул формада, шуны хәтерләткән» мәгънәсен белдерә торган икенче компоненты (мәс., *ромбсыман, калкансыман, дугасыман, порошоксыман* һ.б.ш.)

**-СЫМАННАР** Фәнни классификациядә семьялык яки отрядны белдергән кушма терминнарның «шуның ишеләр, шулар рәтендә булганнар» мәгънәсендәге икенче компоненты (мәс., *алабугасыманнар, чыпчыксыманнар* һ.б.ш.)

**СЫН** *и.* 1) Гәүдә, фигура. *Хосусән аның көязлеге, шактый пөхтә киеме өстенә, чибәрлеге, сынының килешлеге күңелемә дә бераз тәэсир итә иде.* Г.Исхакый. *Өстәлнең икенче ягында утырган Виленның болай да төз сыны тагын да тураебрак китте, аксыл чыраенда канәгать елмаю балкыды.* М.Маликова

2) Гәүдә, сан. *Дөньяга җитлегеп туган, сәламәт Тимербулат нindидер билгесез сәбәптән сыны катып елый, бер тотынса, сәгатьләр буе туктый алмый иде.* М.Маликова. *Ләкин өйдә кадерле кешең хәл эчендә ятканда, сыныңны катырып, чарасыз күз яшьләреңне күпме түгеп була?* Г.Якупова

3) *сәнг.* Кешегә яки башка җан иясенә охшатып, таш, металл, агач һ.б.ш. материаллардан кисеп, кырып, әвәләп яки коеп эшләнгән скульптура әсәре. *Кай ягы беләндер бу сын сиңа охшаган.* С.Сабиров. *Уйный торган балалар сурәтләнгән бәләкәй гипс сын да бар.* Ф.Галиев

4) Кешегә яки башка җан иясенә охшатып ясалган сурәт, рәсем. *Ат сыны*

5) Табыну өчен ясалган скульптура: сурәт, санәм, пот, балбал. *Мәҗүсиләр храмнарында сыннарга корбаннар китерделәр, коммунистлар сәяси белдерүләр һәм патриотик чакырулар белән чыктылар.* Татар мөселман календаре. *Будда сыны. Сыннарга табыну*

**СЫНАЛГАН** *с.* 1) Үзен эштә күрсәткән, үзен аклаган; ышанычлы. *Бу – бер түгел, мең тапкырлар сыналган хакыйкать...* Р.Мөхәммәдиев. *Бу – күп буын студентлар тарафыннан сыналган адым иде.* Р.Зәйдулла

2) Берәр эштә яки хәлдә үзен әйбәт яктан күрсәткән, ышанычны аклаган, тәҗрибәле (кеше тур.). *Ул – минем сыналган кешем, аны безгә теләгән эшкә пычак итәргә була.* Т.Гыйззәт

**СЫНАЛМЫШ** *и. к.* **сынамыш** (*2 мәгъ.*). *Имеш, Вәлихан бабайның бер кулында Коръән булса, икенчесендә төрле сыналмыш язмалар, ди...* Э.Касыймов

**СЫНАЛУ** *ф.* Төрле үзлекләре тикшерелү, сынаулар узу. *Батыр яуда сынала.* Мәкаль. *Шигырь төзелеше мәсьәләләре әле язучылар, тел һәм әдәбият белгечләре җәмгатьчелеге эчендә үсү, сыналу, яшәргә әзерләнү чорын кичерә.* Х.Туфан. *Шунда сынала инде урта звено дигән безнең брат.* М.Хәбибуллин

**Сынала килү** Электән үк, эзлекле рәвештә сыналу

**Сынала тору** Сыналу процессында булу

**Сыналып тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта сыналу

**СЫНАЛЫШ** *и.* Сыналу хәле; сыналу рәвеше; сыналу вакыты. *Ирләр дә, хатыннар да бердәм катнаша сыналышта, сүз боткасына һәркем бер бөртек булса да ярма атып калырга тырыша.* Г.Якупова. *Гомумән, Башкортстанның экологик хәлендә сыналыш чоры җитте.* Я.Шәфыйков

**СЫНАМЫШ** *и.* 1) Сынап карау, тәҗрибә. *Кирам абыйның акыл сынамыш дәресләре һәрвакыт күңелле, һәрвакыт истә кала.* Р.Низамиев. *Инглизчә дәшүем шаяру да, аны хәйран калдырырга ниятләгән алым да түгел иде. Фәнни сынамыш иде бу.* М.Юныс

2) *фольк.* Күпьеллык күзәтүгә нигезләнеп, киләчәктә һава торышы, уңыш, табигатьтәге үзгәрешләрнең нинди булачагын алдан билгеләүдән гыйбарәт халык авыз иҗатының кече жанры; *русчасы:* **примета**. *Шунда бер сынамыш исемә төште: яңа салынган йорт янына мал җыелса, ихатасы бәрәкәтле була, имеш.* Ф.Яхин. *Үзенә иптәшкә дип мине гөмбәгә иярткән иде, шунда Күрәнле елгасы аша чыкканда, аңа әйтеп тә карадым, әнә бакалар ярга чыгып бакылдыйлар, яңгыр явачак (әбием сынамышы) дип, барыбер үзсүзләнеп алып китте.* Г.Якупова

**СЫНАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сынау** I. *Электр челтәрен монтажчыларның үзләреннән сынату*

2) Өметне, ышанычны акламау. *Сынау башлана. Мин үземне тәүге имтихан бирүче бала хәлендә сизәм. Шулай да сынатасым килми. Ышанам, бик ышанам укучыларыма.* Ф.Яхин. *Монда, аз йөрелгән сукмак кебек, тар юл шактый комачаулы иде. Шулай да көр мал сынатмады.* С.Рафиков. *Җирән кашка атыбыз ашауда гына түгел, эштә дә үзен сынатмый иде.* Н.Сәфәрев

3) Хәлнең авыр икәнен сиздерү, хисләрне төс-кыяфәт, хәрәкәт, йөз-чырай һ.б. аша күрсәтү; үз-үзеңне кулда тота алмау. *«Эх, егетләр! Авыртмас башка тимер таяк», – дип уйланды Солтан. Ләкин сер сынатмады, хатынга каты бәрелмәде.* А.Расих

4) *күч.* Берәр эшне булдыра алмыйча, уңайсыз хәлгә калу. *Без дә молодец, сынатмадык, шәп эшләдек.* С.Сабиров

**Сыната башлау** Сынатырга тотыну. *Йөз яшемә җиткәнче ару гына идем дә, быелтырлы-быеллы сәламәтлегем сыната башлады.* Кызыл таң

**Сыната төшү** Бераз сынату. *Җырларда җырланган бу культура соңгы елларда сыната төшә шул.* Саба таңнары

**Сынатып карау** Булу-булмавын тикшерер өчен сынату. *Үземне хәзерге татар әдәби телен яхшы белә торган Казан кешеләре тарафыннан сынатып карау фикере дә туды.* Татарстан яшьләре

**Сынатып кую** Кинәт сынату. *Озын сүзнең кыскасы, гаиләмөлкәтенә куркыныч янау белән үк, «текә кыя»ның бабасы да бу хәлгә тыныч кына карап торалмый, Чечня кампаниясендә шактый таушалган нервылары сынатып кую аркасында, тормыш утының кызуына ташлана.* Ватаным Татарстан

**Сынатып тору** Һәрвакыт яки хәзер сынату. *Балдызының бу сүзләрен Гайфулла үзенә мактау дип кабул итте һәм канәгать рәвештә тамак кырып: – Мондый балдыз алдында сынатып торсаң, — диде.* Ф.Яруллин

**СЫНА́У** I *ф.* 1) Кешенең уңай һәм кире сыйфатларын, хисләрен тикшереп карау; өйрәнү, күзәтү. *Кунак әз утырыр, күп сынар.* Мәкаль. *Кайсы вакытларны ул аны аклап та куя; бәлки, ул да уйланадыр, хисләрен сынарга телидер, шуңар гына хәбәр бирмидер...* Л.Ихсанова. *[Ул] Ак күзле хатыннан башта шикләнеп йөргән иде, ай-ай ярым китә-кайта йөргәннән соң, ул аны сынады, сынагач ышанды, хәтта ничектер якын итте.* Я.Зәнкиев

2) Булганлык, уңганлык, эшлеклелек сыйфатларын кулланып карау. *Шуның өстенә тагын фикерне эшләтү, хыялны җигү, сәләтеңне сынау – иҗатны шулар кабындыра бит инде.* Ә.Еники. *Акылыңны сынау. Көчне сынау*

3) Ясалган, эшләнгән әйбернең сыйфатын, яраклылык, кыйммәтлелек дәрәҗәсен, билгеле бер таләпләргә җавап бирүен рәсми тикшереп бәяләү; эшләтеп, файдаланып карау. *Сорт сынау һәм туфрак структурасын тикшерү максаты белән лабораторияләр булдыруны мин иген игүдәге иң җитди эшләрнең берсе дип аңлыйм.* М.Хәбибуллин

4) Гамәли эш, шәхси тәҗрибәдән, күзәтүләрдән чыгып белү. *Алдагы күзәтүләрдән чыгып, кышның нинди буласын җәй көне сынау*

**Сынап алу** Бераз сынау

**Сынап бару** Эзлекле рәвештә, бер-бер артлы сынау

**Сынап бетерү** Барысын да сынау

**Сынап йөрү** Һәрвакыт сынау

**Сынап карау** Сынау тәҗрибәсе ясау. *Осталыгыңны сынап карау гына түгел, малайлар өчен хис-тойгыларны алмаштыру, тәвәккәллек дәресе дә иде бу.* Р.Низамиев. *Анатолий Спивак, кушаматы «Бомбардир». Кайчандыр бомба ясаган булган, шуны сынап караганда, күршесенең сараен күккә очырган.* Ф.Галиев

**Сынап килү** Билгеле бер вакыт дәвамында эзлекле сынау. *Чын яз башлана. Мин аның шулай икәнен тәҗрибәгә салып, егерме еллап сынап киләм.* С.Рафиков

**Сынап тору** Даими яки регуляр рәвештә сынау

**Сынап чыгу** Барсын да, бөтенесен дә сынау

**Сыный килү** Билгеле бер вакыт дәвамында сынауны дәвам итү

**Сыный төшү** Бераз сынау; тагы да ныграк сынау. *Ул күкрәгенә ялтырап торган «Батырлык өчен» медале таккан разведчикка сыный төшеп карап торды да сул кашын чак кына сикертеп елмайды.* Г.Әпсәләмов

**СЫНА́У** II *и.* 1) Имтихан. *Самат күп көттермәде – июнь урталарында ук сынауларын тапшырып бетерде дә авылга очты.* Г.Гыйльманов. *Ярты ел саен сессия: сынау, зачётлар, контроль эшләр, семинарлар, китапханәдә казынырга кирәк...* Р.Кәрами

2) Әйбернең яраклылык дәрәҗәсен, таләпләргә җавап бирү сыйфатын тикшереп бәяләү, эшләтеп карап, файдалылыгын билгеләү эше. *Эшебезне пыр туздырып, мөдирнең утыз еллык эш стажын да искә алмыйча, безгә бер айлык сынау срогы бирделәр.* Х.Сарьян

3) *күч.* Кыенлыклар, төрле авырлыклар, киртә. *Шул ук вакытта аны [Равилне автор] берөзлексез яңа сынаулар, яңа киртәләр алдына куя тора.* В.Нуруллин. *Шулай итеп, Ильясның мәхәббәте, күп сынаулар үтеп, күңелдә йөргән икеләнү-шикләнүләрне җиңеп чыга.* Р.Зарипов

**СЫНАУЛЫ** *с.* Сынаган, сынауны белдерә торган. *Хорошев, исе китми генә, Розага сынаулы караш ташлады.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Хуҗаның ачык күңеллелеге, бер генә минутка да өстәл янына утырып карамаган улларының кунакларны чын күңелдән хөрмәтләүләре сынаулы шикне юкка чыгарды.* Г.Шәрипова. *Хөсәен абыйның: «Ник әйтер икән бу?» – дип, йотылырдай булып Кашшафка текәлгән сынаулы күзләре чын канәгатьләнү белән балкып киттеләр.* Р.Төхфәтуллин

**СЫНАУЛЫК** *и.* **1.** Проба, анализ өчен материал. *Кан сынаулыклары алу*

**2.** *с. мәгъ.* Тикшерүгә, сынауга алынган; эксперименталь. *Сынаулык көлтә*

**СЫНАУЧАН** *с.* **1.** Күзәтеп-сынап караучан. *Шул ук вакытта аның үзүзен тотышы, зәңгәр күзләренең сынаучан җылы карашы кешене үзенә җәлеп итә, аңарда ихтыяр көче сизелеп тора.* С.Сабиров. *Теге шунда ук сынаучан карашын Мостафинга чекерәйтте.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* Сынап, тикшереп, күзәтеп. *Илмира бер кулын суга тыгып бара, кысыла төшкән күзләре шаян елмаеп һәм сынаучан карый.* Г.Әпсәләмов. *Зәйнәп белән Гәрәй, эчкә кермичә, аларны тышта көтеп торырга булдылар һәм, икәү генә калгач, берберсенә сынаучан карашып алдылар.* С.Сабиров

**СЫНАУЧЫ** *и. махс.* Берәр яңа әйберне тикшереп, сынап караучы, сынау үткәрүче; сынау белгече. *Атасы автомобиль заводында сынаучы техник, анасы – фельдшер.* М.Насыйбуллин. *Ә бит әле ул сугыштан соң да дистә еллар буенча яңа самолётларны сынаучы булып эшли.* Ф.Яруллин

**СЫНАШ** *и.* Сынау (I) эше, сынау гамәле. *Көч сынаш*

**СЫНАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **сынау** I. *Ассистент профессорга агрегатны сынашты*

2) *күч.* Ярышу, көрәшү. *Әмма хан батырлар өчен көч сынашу – ат чабышы бәйгесе уздырырга булган икән.* Т.Нәбиуллин. *Беренче заездда – нәселле, ярымнәселле атлар, икенчесендә җирле атлар сынашты.* Кайбыч таңнары

**Сынаша башлау** Сынашырга керешү. *Билгеле булганча, мондый чараларда спортчылар ачылу тантанасына бер көн кала көч сынаша башлый.* Ватаным Татарстан

**Сынаша бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сынашу

**Сынашып алу** Тиз генә, бер тапкыр сынашу

**Сынашып карау** Нәрсәне дә булса билгеләр өчен сынашу. – *Әй, Гыйфрит, синең яратмаган адәмең менә мин ул, әйдә, көчләребезне сынашып карыйк әле, – дип әйтте, ди.* Әкият

**Сынашып тору** Даими яки хәзерге моментта сынашу

**СЫНДЫРУ** *ф.* 1) Каты әйберне көч белән аркылыга чатнату, ике кисәккә аеру. *Түбәнтен генә очып үткән бер снаряд мачтаны төптән кискәндәй сындырып китте.* С.Сабиров. *Байтак йоклаганмы – белмәде, кемдер берәүнең коры чыбыклар сындырып узуы колагына кереп сискәнеп уянды.* Я.Зәнкиев

2) *физ.* Яктылык һ.б.ш. агымын, нурларын чагылдырып юнәлеш үзгәртү. *Яктылыкны сындыра торган системалар, яктылык нурларының сыну дәрәҗәсен үзгәртә торган аккомодацион җайланмалар һәм, ниһаять, әйләнә-тирәдә күренгән нәрсәләрне актив эзләргә мөмкинлек бирә торган хәрәкәтләндерү аппаратын гына булдырасы кала.* Кызыклы физиология

3) *күч.* Салкынлык сизелерлек кимү, кинәт җылыту. *Җыелган картлар арасыннан Ак бабайга атап әйткән сүзләр ишетелде: – Хәтмулла ахири, кара әле, яңгыр булачагы чын дөрес аның... көнне сындырыр, ахры, бар тәнем сызлый.* Г.Гыйльманов. *Кояш бөтен җылысын, яктысын, дәртен кышны сындыруга җиккән, җиргә көлтәләп җылы нурларын коя гына.* Г.Якупова

4) *күч.* Килешергә, буйсынырга мәҗбүр итү; җиңү, бетерү. *Әгәр ятимлек измәсә, ачлык-ялангачлык рухын сындырмаса, Ырсытдиннең байбичәсенә буйсынып торыр идеме ул?* Я.Зәнкиев. *Нинди генә каршылыкларны җиңәргә, кемнәрне генә сындырырга туры килмәде аңарга.* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Бетерелү, туктатылу. *Совет сугышчылары, дошманның каршылыгын сындырып, каршы ярда ныгый.* Ватаным Татарстан

6) *күч.* Исерткеч эчү, салу, кагу. *Эштән соң иске дусты белән бер ярты сындырырга җыенган Мидхәтнең кашлары җыерылып килде.* Р.Зәйдулла. *[Аның] Көн буе ресторанга әрҗә ташып хәле беткәндер, эштән соң бер ярты сындырса да, күңеле күтәрелмәгәндер.* М.Маликова

7) *күч.* Бозу, гамәлдән чыгару. *Ул, кичке ахшам намазын укыганда, намазлык өстендә тәһарәтен сындырган, оятсыз!* Р.Батулла

**Сындыра бару** Эзлекле рәвештә сындыру

**Сындыра башлау** Сындырырга тотыну. *Хайваннар еш кына егыла, аякларын сындыра башладылар.* Т.Нәбиуллин. *Ир чыбыкларны берәм-берәм сындыра башлый.* Р.Батулла

**Сындыра бирү** Һичнәрсәгә карамыйча сындыру

**Сындыра килү** Бер-бер артлы сындыру

**Сындыра тору** Ниндидер эш эшләнгәнче, шуның белән бер вакытта сындыру. *Мин тагын чыбыкка барам, син боларын сындыра тор.* Р.Батулла

**Сындыра төшү** Бераз сындыру

**Сындырып алу** Тиз генә сындыру

**Сындырып бетерү** Барысын да сындыру. *Бик күп агачларны сындырып бетерәләр.* Әкият. *Шулай «очаоча», кул-аягын сындырып бетерде.* Г.Гыйльманов

**Сындырып җибәрү** Кинәт сындыру. *Кайбер сындырып җибәргән кышның җылымса көннәрендә каяндыр көньяк тарафыннан килеп чыга да, аваз салып, биләмәләренә күз ташлап китә.* Ф.Яхин

**Сындырып карау** Булу-булмавын тикшерү өчен сындыру. *Инде хәзер һәр чыбыгын берәмтекләп сындырып карагыз.* М.Галәү

**Сындырып кую** Сынган хәлгә китерү. *Иң соңыннан, сынмый калган көнбагыш сабагын аягы белән егып, сындырып куйды, шуннан гына канәгать калды.* Идел

**Сындырып ташлау** Тиз генә яки ачу белән сындыру. *Чатны да борыла Бикмуш бабай. Һәм... монда аның соңгы канатын да сындырып ташлыйлар.* Г.Гобәй

**Сындырып тору** Даими, регуляр яки хәзер сындыру

**Сындырып чыгу** Бөтенесен дә сындыру

**СЫНЛАНДЫРУ** I *ф.* Нинди дә булса образда, предметта сурәтләү; гәүдәләндерү. *Борынгылар мифологик фикерләүгә, ягъни төрле нәрсәләрне җанландыру, сынландыру, үзара тиңләштерү, кешеләштерүгә нигезләп, ассоциатив образлар, стихияле тропсурәтләр, хикәятләр тудырганнар.* М.Бакиров

**СЫНЛАНДЫРУ** II *и. әд.* Җанлы нәрсәләрнең үзенчәлекләрен табигать күренешләренә һәм жансыз әйберләргә күчерүдән гыйбарәт сәнгатьле сурәтләү алымнарының бер төре. *Юмор әсәрләрендә, жанр үзенчәлеге таләп иткәнчә, эпитет, чагыштыру, метафора, гипербола, литота һәм сынландыру алымы да, әлбәттә, комик рухта була.* Х.Курбатов

**СЫНЛАНУ** *ф.* Формалашу, билгеле форма, рәвеш алу; нинди дә булса образда, предметта гәүдәләнү

**Сынлана башлау** Сынлану билгеләре күренү; сынланырга тотыну. *Кибән сынлана башлагач, бозлавык таудан арты белән шуган малай сымак, ул кире шуып төшә.* М.Кәрим

**СЫНЛЫ** I *с.* Сыны, гәүдәсе, фигурасы билгеле үзенчәлеккә ия булган. *Араларыннан берсе дә пристань читенә басып үзләрен ипле генә күзәтеп торган баһадир сынлы егетне абайламады.* Р.Мөхәммәдиев. *Менә ярга терәлеп диярлек, ике ялангач гәүдә калка: атлет сынлы егет белән ифрат сылу гәүдәле кыз, җитәкләшеп, ярдан күтәрелә башлыйлар.* Ж.Дәрзаман. *Әмма гәүдәсе сылап куйган төсле туптуры сынлы.* Н.Дәүли

**СЫНЛЫ** II *бәйл. диал.* Шикелле, сыман, кебек, күк. *Әгәр дә --- ул кызыл алманы зур кара күзле, кара бөдрә чәчле --- кыр кәҗәсе сынлы унҗиде яшьлек кыз, җирдән алып --- механик-водительгә киртә аша ыргытмаса, әгәр шул кызыл алма солдатның күкрәгенә килеп тимәсә, бу фаҗигале хәлләр, әлбәттә, булмас иде...* М.Кәрим

**СЫНЛЫЛЫК** *и.* Билгеле сынга, фигурага ия булу. *Карчык әйтте: – Бер кызы бар, әмма күк астында, җир өстендә аның кебек адәм юктыр. Чин-Мачинда, Хита вә Хотанда, Рум, Бол-*

*гарда кипарис сыман төз сынлылыкта, зифа буй-сында, бөеклек дәрәҗәсендә аның кебекне Хак Тәгалә моңа кадәр очратканы юктыр.* Мәҗмугыл-хикәят

**СЫНЛЫ́ СӘНГАТЬ** *и. махс.* Тасвири сәнгатьнең каты яки пластик материаллардан күләмле әсәрләр ясау төре. *Бөтен күңелен сынлы сәнгатькә биргән кеше арабызда ул гына булгандыр.* М.Әмир. *Безнең бригада шушы елганың түбәнге агымында күптән түгел генә төзелә башлаган электр станциясе корылмаларын сынлы сәнгать фигуралары белән бизәргә тиеш.* С.Сабиров

**СЫН-СЫЙФАТ** *җый. и.* Гәүдә, буй, тән төзелеше

**СЫНУ** *ф.* 1) Гадәттә озынча каты әйберләр бәрелүдән, бөгүдән яки башка көчле кискен тәэсирдән аркылыга чатнау, икегә аерылу. *Утыргычның соңгы аягы да шартлап сынды.* А.Расих. *Шарт-шорт итеп миллеккә дигән каен ботакларының сынганы гына ишетелеп торды.* Г.Якупова

2) *физ.* Юнәлешен үзгәртү (бер физик мохиттән икенчесенә күчкән яктылык, нур, төрле дулкыннар тур). *Яктылыкны сындыра торган системалар, яктылык нурларының сыну дәрәҗәсен үзгәртә торган аккомодацион җайланмалар --- гына булдырасы кала.* Кызыклы физиология. *Яктылык нурының сыеклыкта сыну почмагы $p = 30^o$.* Физика

3) *күч.* Көчле салкын көннең кинәт җылынып китүе. *Көн сыну*

4) *күч.* Килешергә, ризалашырга, буйсынырга мәҗбүр булу; рухи җиңелү, бирешү. *Инде бу хәлдән соң кеше я сынарга, я җир йөзеннән югалырга тиеш иде.* Х.Ибраһим. *Рүзәлнең әле генә йодрык төенләп сугышка күтәрелгән, гомерен җәлләмичә ачлык мәйданнарына чыккан каһарманы беренче каршылыклардан ук сына, тиз арада элекке гамәлләрен сантыйлык дип саный.* Идел

5) *күч.* Туктау, бетү (каршылык һ.б.ш. тур.). *Бер капчык алма тутырып илтсәң, Йосыфҗанның кирелеге сына...* Ә.Фәйзи

**Сына башлау** Сынырга тотыну. *Эсселек аркасында, чүп үләне кебек үсә торган укропның, үзен-үзе тотып тора алмыйча, сабагы сына башлады хәтта.* Ватаным Татарстан

**Сына килү** Эзлекле рәвештә, электән үк сыну. *Хакыйкать муены бервакытта да сынмый, ә менә хакыйкатьне сындырырга теләүчеләрнең муеннары сына килде һәм сыначак та.* И.Туктар

**Сынып бетү** Бөтенесе дә сынган хәлгә килү

**Сынып калу** Берәр вакыйгадан, хәлдән соң сыну. *Биредә зур-зур ташлар, кайчандыр кагылып һәм сынып калган субайлар башы чыгып тора иде ---.* М.Хәбибуллин. *Як-якта сынып калган ботаклар, Уктауга киткәндә тапталганнан тураеп өлгермәгән үләннәр юлны күрсәтеп тора.* Г.Якупова

**Сынып китү** Кинәт сыну. *Якынлашып килгән ак пароходка карап гасабиланган Сәрвәр үзе тотынган ботакның сынып китүен соңыннан гына абайлады.* Я.Зәнкиев

**Сынып чыгу** Бөтенләй, тәмам сыну. *Моңа хәтта чыбык та түзмичә, бернichә җиреннән сынып чыкты.* Н.Сәфәрев. *Барый абый, зинһар, коткара күр, нәкъ гәзит басып ятканда, урта бәлүк сынып чыкты.* А.Хәсәнов

**СЫНУЧАН** *с.* 1) Тиз сына торган, сынуга бирешүчән. *Фрагментация барышында коры һавада тиз сынучан катлама җил исүдән, хайваннар яки кеше орынудан сынып тарала.* Ботаника

2) *күч.* Тиз килешергә, ризалашырга мәҗбүр булган; рухи яктан тиз җиңелә, буйсына торган (кеше тур.). *Ул түзем табигатьле күренә, ләкин бөгеләсыгыла белмәгән кеше тиз сынучан була...* Х.Камалов

**СЫНУЧАНЛЫК** *и.* Сынучан булу. *Болар чәчне артык электрлашудан да саклаячак, сынучанлыгын да киметәчәк.* Ялкын

**СЫНЧЫ** *и.* Сын (*4, 5 мәгъ.*) ясаучы кеше; сынлы сәнгать остасы; скульптор. *Булды заманнар: теге яки бу халыкның байрак символы итеп бөек шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, сынчылар, гомумән сәнгать кешеләре саналды.* Р.Фәйзуллин

**СЫНЫК** *с.* **1.** 1) Сынып, бөтенлеге, төзеклеге бозылган; сынган. *Мәктәп урынында черек-чарык кисәкләре, сынык такта, кәгазь-мәгазь, гомумән, өй сүткәндә кала торган мең төрле нигез чүбе генә таралып калды.* Г.Мөхәммәтшин. *Кыз сынык чаңгысына карап елмайды һәм ни әйтергә дә белми уйга калды.* М.Хәбибуллин

2) Төзек булмаган, бозылып күренгән. *Горжецкий саный башлаган иде дә, каршыдагы теплушкаларга сынык күләгә төшереп депога таба йөгерешеп үткән тимер юлчыларны күргәч, исәбен бутады.* К.Нәҗми

3) *мат.* Бер-берсе белән почмак ясап тоташа торган турылардан гыйбарәт (сызык тур.). *Бу тигезсезлекнең уң кисәгендәге сумма С дугасына камалган сынык сызыкның периметрына тигез.* С.Хәйруллин

4) *күч.* Боек, кәефсез, төшенке, кайгылы (кеше, күңел тур.). *Халык шул хәтле яратты үзен, ул килмәсә, бөтенесенең күңелләре сынык була иде.* Э.Касыймов. *Сынык күңелдә бер аяусыз сорау гына тере калды: «Бер-бер чиге булырмы моның, Ходаем!»* Я.Зәнкиев

5) Төшенке, боек халәтне белдерә торган (тавыш, аваз һ.б.ш.). *Ул яшь аркылы, сынык тавышы белән иренә сораулар бирде.* Ә.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бөтенлегенә зыян килгән әйбер; бөтеннән кителеп төшкән өлеш. *Кесәсен актарып, ул аннан сөяк тарак сыныгы китереп чыгарды.* Ф.Галиев. *Шунда кәгазь белән карандаш сыныгы табып, үзенең васыятен язып өлгерә.* К.Кәримов

2) Бөтеннән сындырып яки кисеп алынган өлеш. *Җыелган икмәк сыныклары арасыннан тәмлерәген сайлый башлыйсың...* М.Әмир. *Малай ипи сыныгын учына чытырдатып кысып басып тора ---.* М.Маликова

◊ **Сыныкка сылтау** Аклану яки кемгә дә булса бәйләнү, гаепле итеп калдыру өчен китерелгән нигезсез дәлил, сәбәп. *Алар исә һаман сыныкка сылтау табалар, акча юклыкка сылтыйлар.* Р.Миңнуллин. *Ялкау өчен сыныкка сылтау табыла тора.* Р.Батулла. *Беләсең ич инде, ташла барысын да, кил калага, диюләре – сыныкка сылтау гына ул...* Р.Мулланурова

**СЫНЫКЛЫК** *и.* Сынык булу. *Әтисе өйгә үги әни алып кайткач, күңел сыныклыгы тирә-юньгә ачу, нәфрәт булып ташып чыга.* С.Хәкимова

**СЫНЫК-САНАК** *җый. и.* 1) Төрле әйберләрнең сынган, сынгаланган кисәкләре. *Аннан-моннан гына тунап, иң йомшак итен алганнар да калган сынык-санакларны абзар буенда чәчеп калдырганнар.* Г.Гыйльманов

2) Камыр ашларыннан калган кисәкләр, калдыклар. *Менә шулай һәр көнне өй борынча урам йөреп, озын киндер капчыкларын сынык-санак белән тутырып, безнең «чәйни» янына кайталар икән дә, баскыч төбенә утырып, барлык җыйганнарын бушатып, сортировать итәргә тотыналар икән.* Ә.Еники

**СЫНЫК-САНЫК** *җый и. к.* **сынык-санак**. *Аңар өеннән сынык-санык алып килеп каптырды. Ләкин өйдә ашау-эчү ягы һаман да бик кысан иде әле: ипи-күмәч сирәк була, күбесенчә, иртә-кич буш аш белән генә калалар, аны да әниләре бүлеп кенә бирә иде.* Г.Гобәй

**СЫНЫШ** *и. физ.* Юнәлеше үзгәрү күренеше (нурлар, дулкыннар тур.). *Нурлар сынышы*

**СЫҢАР** *с.* **1.** 1) Икеле, парлы нәрсәнең берсе булган. *Без бәләкәй чакларда, сыңар чиләк белән суга йөрү юк иде.* М.Маликова. *Курку көчле булгандыр, мин әле сыңар итек белән дә байтак кына йөгергәнмен.* Р.Мөхәммәдиев

2) Бик әзәйтеп, киметеп сурәтләү чарасы буларак: иң соңгы, бер генә, бердәнбер. *Киявенә дә кул бирмәде, сыңар сүз катмады, өенә алдырмады.* Р.Зәйдулла. *Моннан догадагы ак әбиләр яхшы күренеп тора. Ә күктә сыңар болыт та юк.* Ф.Яхин. *Ул кичә бодай кыры эчендә калган сыңар көнбагышны сурәткә төшерә башлаган иде, кояш болытлар арасына качып, көн сүрәнләде дә, эше бүленде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ. тарт. форм.* Исемнән яки алмашлыктан соң килеп, «шуның ише, пары, шуңа охшаш нәрсә» дигәнне белдерә. *Бусын мин, пәке алып, бик тиз рәтләдем. Әмма бер сыңарының очлы башлы, икенче сыңарының тупа башлы булуын берничек тә бетереп булмады.* Ә.Шамов. – *Черчиль мәлгунь, Рузвельты да шуның сыңары, «икенче фронт»ны һаман да ачмыйлар, – дип сөйләп китте ул.* А.Хәсәнов. *Әмма чагыштыру өчен телнең хаҗәте юк – күз бар ич. Чагыштырдым: үзем дә шулар сыңары икәнмен, ягъни кыз бала.* Г.Якупова

**СЫҢАРКҮЗ** *и. зоол.* Кысласыманнар семьялыгыннан бер күзле төче су хайваны; *русчасы:* **циклоп**

**СЫҢАРМӨГЕЗ** *и. зоол.* Дельфиннар семьялыгыннан өске казналыгында озын казык теше үсеп чыккан, сирәк очрый торган имезүче диңгез хайваны; нарвал

**СЫҢАРСЫЗ** *с.* Парсыз, икенче сыңары җитмәгән. *Сыңарсыз бияләй*

**СЫП-** Кайбер сыйфатлар белән килеп, шуның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Минем Әсма ахирәтем, болар белән чагыштырганда, сып-сылу бичура булган икән теге карнавалда.* Г.Якупова. *Сып-сыек чәй*

**СЫПКЫ** *и. рус диал.* Пычрак. *Көчәнеп алга ыргылып карады – кузгала алмады, тәгәрмәчләр сыек балчыкта сыпкы боламыгы болгатып зыр-зыр әйләнделәр.* А.Гыйләҗев

**СЫПТЫРТУ** *ф. к.* **сыптыру**. *Безнең белән көчлеләр генә кала, ялкаулар сыптырталар.* А.Гыйләҗев

**СЫПТЫРУ** *ф.* 1) Сугу (чыбык, камчы һ.б.ш. нәрсә белән). *Сәлмән шулай дип сорады да, сикерә-сикерә, чыбыгы белән Рафисның шәрә балтырына сыптырырга тотынды.* Х.Хәйруллин. *Алай да аңламагач, ишегалды селберкесе белән дә берәрне сыптыргаладым.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Кызу-кызу, тиз генә бару, йөгерү. *Ул аяк астына карамый-нитми турыга гына сыптыра, аркасында ике көпшәле ау мылтыгы селкенгәләп бара иде.* Г.Ахунов. *Биектау ашханәсенә кереп бер стакан чәй эчтем дә авылга сыптырдым.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Тиз генә китү, качу. *Безнең промыселда берәү Түбән ягына сыптырырга чамалап тора.* Э.Касыймов. *Рәзил олылардан күз яздырып балыкка сыптыру ягын карады.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Талымсыз һәм капыл-копыл ашап-эчү. *Әйтергә кирәк, монда да начар ашатмыйлар. Көненә өч мәртәбә шартлаганчы сыптырабыз.* Г.Мөхәммәтшин. *Иртән тозга ярып пешергән әмерхан бәрәңгене кара ипи белән сыптырсаң, бер-ике стакан сөтле чәй эчсәң, бу дөньяда бүтән берниләрең дә кирәкми.* М.Мәһдиев. *Шилов блиндаж авызында иртәнге ашны сыптырып утыра иде.* Х.Камалов

5) *күч.* Урлау, чәлдерү. *Авыл малайлары да аналарының берәр нәрсәсен сыптырып тотылгач: – Кояштыр, алмадым! – диләр, Кояшны якасыннан тотып шаһитлыкка өстериләр.* Һ.Такташ

**Сыптыра башлау** Сыптырырга тотыну. *Килеп җитүгә, чык суларына манчылган яшел үләннәрне мышныймышный сыптыра башладылар.* Т.Гыйззәт

**Сыптыра бирү** Бернәрсәгә карамыйча сыптыру

**Сыптырып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә сыптыру. *Бер-ике тапкыр селберке очы белән миңа да сыптырып алды.* Т.Миңнуллин. *Мин, ачуланып, сыртына дилбегә очы белән сыптырып алам.* Г.Галиев

**Сыптырып бетерү** Барысын да сыптыру

**Сыптырып җибәрү** Кинәт кенә сыптыру. *Камил Галләмнең кулындагы камчысына карап куйды да, сыптырып җибәрмәгәе дип, артка чигенде.* Ш.Бикчурин. *Килде-китте сөйләп ачуымны кабартмасана, я сыптырып җибәрермен...* М.Әмирханов

**Сыптырып кую** Кинәт, бер мәртәбә, бик тиз сыптыру. *Миңнурый белән Фаягөл уяндылар, бер-берсен шаярып үчекләп юындылар, иплә кенә бәрәңгене сыптырып куйдылар.* Я.Зәнкиев

**СЫПЫЛУ** *ф.* 1) Бәйләнгән, суккан нәрсәнең (тукыманың) җепләре сүтелү, ычкына башлау. *Итәге киң – кыңгырау чәчәге төсле, путасы билен дүрт тапкыр урап алырга җитә, нәфислеге тиңсез... күлмәгенең күкрәк өлеше тәненә сыланган кебек, кыз сулыш алса сыпылып чыгар төсле.* К.Кәримов

2) Җыеп куйган җирдән ычкыну, аерылып төшү. *Бит алмалары комач кызыл, мамык шәл кырыйларына, сыпылып чыккан чәч бөртекләренә мул*

*булып кунган бәс кыйммәтле ташлар кебек җем-җем итә.* М.Хәсәнов

3) Сытылып күздән яшь килү. *Җиһангирның күзеннән ике яшь бөртеге сыпылып чыкты да яңаклары буйлап тәгәрәде.* Н.Хәсәнов. *Мостафа агайның төсен җуйган күзләреннән сыпылып чыккан ачы яшьләр бите буйлап чал сакалына агып төшә.* Ф.Сафин

**Сыпыла бару** Әкренләп сыпылу

**Сыпыла башлау** Сыпылырга тотыну. *Шулай итеп, егерменче гасыр башында Каргалы имамнарының гасырлар буе бөртекләп җыйган абруе сизрәп төшкән мендәр сүрүе кебек сыпыла башлады.* Ф.Сафин

**Сыпыла бирү** Бернәрсәгә карамыйча сыпылу

**Сыпылып бетү** Бөтенләй, тәмам сыпылу. *Сыпылып бетмәсен өчен, җөйләрне эчке яктан эшкәртеп чыгарга кирәк.* Сөембикә

**Сыпылып китү** Кинәт сыпылу

**Сыпылып чыгу** Бөтенләй сыпылу. *Аларның кайсы ясалма ефәк булып, бер юуга сыпылып чыкты, икенче бер төрлесе иләктәй сизрәде.* М.Мөхәммәт. *Соры берет астыннан сыпылып чыккан чәчләре тирле маңгаена ябышкан.* С.Сабиров

**СЫПЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **сыпыру**

2) *күч.* Бернәрсәгә дә игътибар итмичә йөгерү яки кызу-кызу бару. *Тыел, явыз! Акчаңны ал, югыйсә бар мөлкәтеңне мунча мичендә яндырам. Сыпырт моннан!* Я.Зәнкиев. *Юк, үзенең коялы оҗмахы Молдавиягә сыпыртмады егет: ул нибары иске Чаллы читендә --- ялтыравык никельле койкага хуҗа булып алган иде.* Э.Касыймов

3) Качып китү. *Уфадан инде Акъякупка сугылмый да кайтып була: Имәнлек урманы аша туп-туры авылга сыпыртасың.* М.Кәрим. *Самарда чын фронт купканын ишеткәч, аткоралларын алып, шунда сыпыртканнар.* И.Низамов

4) *күч.* Эшне тиз-тиз генә, тоташтан һәм җитез итеп эшләп бетерү. *Бөтен эшне рәттән сыпыртту*

5) *күч.* Талымсыз, барысын да ашап бетерү, бернәрсә калдырмыйча ашаучү. *Биш-ун минуттан без өстәл өстендәге табак белән итне, мактыймактый, кераәнләп сыпыртып утыра идек инде.* М.Мәһдиев. *Тик малай сөтле чәен сыпыртып та өлгермәде, әтисен ашыгыч кына фермага чакыртып алдылар.* Р.Низамиев

6) *күч.* Урлау, чәлдерү

**Сыпырта бару** Бер-бер артлы барысын да сыпырту

**Сыпырта башлау** Сыпыртырга тотыну. *Юлдашлары, аның кебек үк гитлерчылар ягына үз ирекләре белән авышкан сатлыкҗаннар, сугыш безнең ил файдасына борылуга, җайлапҗайлап төрле илләргә сыпырта башладылар.* Я.Зәнкиев

**Сыпырта бирү** Бернәрсәгә карамыйча тиз-тиз сыпырту (йөгерү, атлау)

**Сыпырта тору** Берәр хәл булганчы сыпырту

**СЫПЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне тигезләргә тырышып, шуның өстеннән кулны шудыртып үткәрү. *Бала итәкле күлмәген сыпыргалады, яулыгын төзәткәләде.* Ә.Гаффар. *[Кунак] Якындагы урындыкка утырып, ашыгыпашыгып, мыдыр-мыдыр нидер укыды да, куе йон баскан битен җиңел генә сыпырып, фатиха бирде.* Я.Зәнкиев

2) Кулны шудырып, ышкып, берәр нәрсә өстендәге чүпне һ.б.ш. себереп төшерү, сөртү. *Күзләре җиргә карый, бер бармагы белән прилавка өстендәге вак балчык кисәкләрен сыпыра.* Ш.Маннур

3) Иркәләп сыйпау. *Мәченең аркасын сыпыру*

4) *диал.* Себерү. *Идәнне сыпыру*

5) *күч.* Камчы, чыбык кебек әйбер белән сугу. *Чыбыркы белән берне сыпыру*

6) *күч.* Йөгерү, кызу-кызу бару; качу. *Поезд туктау белән, кире якка төшеп, алгарак сыпырдым.* Ә.Баян

7) *күч. сөйл.* Бер әйбер калдырмыйча, бөтен булганы белән җыеп алу, бөтенесен алу. *Барлык алтын-көмешне сыпыру*

8) *күч.* Комсызланып, талымсызланып ашау. *Сыпыралар гына: балыклар оча, сумсалар бии-бии егетләр авызына шуа тора, Гыйззәтбану түти алъяпкыч итәген кайтарып күз яшьләрен сөртә, егетләрнең ашавына сокланып карап торган Сәгъдетдиннең йөрәге сызлый, ниндидер бәла сизенеп авырта.* Я.Зәнкиев

9) *күч.* Урлап алып китү, чәлдерү

10) *күч.* Эшне җитез һәм тоташтан эшләү

**Сыпыра бару** Бер-бер артлы барысын да сыпыру

**Сыпыра бирү** Бернәрсәгә карамыйча сыпыру

**Сыпыра тору** Берәр хәл булганчы сыпыру

**Сыпыра төшү** Бераз сыпыру

**Сыпырып алу** Тиз генә сыпыру. *Ул сискәнеп китте, кулы белән маңгаен учлап тотты. Аннары учы белән битен сыпырып алды.* Ф.Галиев. *Ләйлә, стенага терәп куелган утыргычны җайлап, кулы белән сыпырып алды, үзе дә утырып, әнисенә таба иелде.* М.Маликова

**Сыпырып ату** Кинәт яки тиз арада сыпыру. *Безнең арада утырган укытучыларыбызга рәхмәтләр укый-укый, өстәл өстенә куелган сый-нигъмәтләрне сыпырып аткач, укучылар шау-гөр килеп төрле уеннар уйнарга тотындылар.* Х.Ибраһим

**Сыпырып бетерү** Барысын да сыпыру. *Башта чактагы кебек назланып, кыстатып утырмас иде Фаягөл, тау кадәр өеп китерсәләр дә, бөтенесен сыпырып бетерер иде.* Я.Зәнкиев. *Хатын-кызга хас тотнаклылыгы булмаса, алдындагын тоташ сыпырып бетерер иде.* Г.Якупова

**Сыпырып җибәрү** Кискен хәрәкәт белән, кинәт сыпыру. *Үзенең әбисе алдында «фәнни яктан» сер сынатуына ачынып булса кирәк, ул юл буендагы куакны кулы белән сыпырып җибәрде, җиргә ялтырап яңгыр тамчылары коелды.* Дөньяда нилэр бар

**Сыпырып кую** Бер тапкыр сыпыру. *Ул имән бармак бите белән Хөсәеннең кыска гына калдырып кырылган кара нәзек мыегын сыпырып куйды.* А.Расих. *Сөббух абзый бүреген салып, кәләпүштән генә калды, ашыкмыйча, салынкы мыекларын сыпырып куйды.* М.Маликова

**Сыпырып ташлау** Кискен хәрәкәт белән сыпыру. *Зәйтүнәнең моңача булган беркатлы бала күңеллелеге, кул*

*белән сыпырып ташлагандай, әллә кая югалды хәзер.* Ш.Маннур

**Сыпырып тору** Әледән-әле яки һәрдаим сыпыру. *Шул врач әйтә: «Хатыны ир кешенең көненә ким дигәндә бер тапкыр аркасыннан сөеп, башыннан сыпырып торырга тиеш», – ди.* Аманулла

**Сыпырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр сыпыру

**СЫР** I *и.* 1) Сызык рәвешендәге эз, чыгынты яки кирт. *Басу йөзендә төзелмәс җәрәхәтләр булып, әрлән балчык сырлары сузылып китә, тегендә дә, монда да шыксыз шадралар ишәя бара...* Э.Касыймов. *Ишек яңагына тагын бер сыр өстәлде. Елның-елында Миләшнең буен үлчәп, пычак белән сыр билгеләп куя Һәдия.* Г.Якупова

2) Тәндәге җыерчык. *Елмайган чагында аның тигез кара кашлары югары чөелеп, маңгаенда байтак кына сырлар хасил булды ---.* Э.Касыймов. *Дулкынланудан аның маңгаенда сырлар калыкты.* М.Насыйбуллин

3) Бизәү сәнгатендә, рәсемдә, язуда һ.б.ш.: сызыклы элемент, нечкәләп, бизәкләп эшләнгән сызык. *Чак кына төшереп алган Хәниф абзый алдында яткан тактага сырлар ясый, ә үзе бертуктаусыз сөйләнә ---.* Г.Гыйльманов. *Роман сыннарына караганда готик сыннарда кешеләрнең кыяфәте төгәлрәк бирелә, кием сырлары астында гәүдә рәвеше ачыграк сиземләнә, сурәтләнгән образлар да хәрәкәтчәнрәк булып күренәләр.* Урта гасырлар тарихы

4) *диал.* Киемнең чит-читенә тегеп куелган тар тасма; кәйтән. *Итәк очына сыр тоту*

**СЫР** II *и. рус* Сөткә махсус эретә торган ферментлар һәм бактерияләр кушып ясала торган каты яки ярымкаты ашамлык төре; пәйнир. *Кыскасы, кая монда ниндидер колбасаларга, сырларга чират торырга вакыт калсын, ди?* В.Нуруллин. *Тауларга безнең кебек бер рюкзак консервы, колбаса, сыр күтәреп чыкмыйлар.* А.Хәсәнов

**СЫРА** *и.* 1) Арпа салатыннан ясала торган җиңелчә исерткеч эчемлек. *...Ике-өч көннән, Кушнаренда йөк калдырырга туктагач, егетләр мактый-мактый сырага ябырылдылар. Марс та берничә шешә алып керде.* И.Низамов. *Вахит абыйсы бик тә тыйнак кеше булып чыкты: профессор дип борынын чөйми – студент хисабына бик шәпләп сыра лыкыды, тартыныпборгаланып тормады.* Х.Ибраһим

2) Йорт квасы. *Әти белән әлеге авылдаш үзләре түргә узып самавыр янына утырдылар. Аның малае белән безгә калын гына бер телем калач, бер стакан йорт сырасы тоттырдылар.* Г.Бәширов

◊ **Сыра мичкәсе** Зур, юан корсаклы, күп эчә торган кеше

**СЫРАҖ** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан чуар яфраклы, терлек ашамый торган агулы күпьеллык үләнчел үсемлек; бакча гөле итеп тә үстерелә; *русчасы:* **норичник**

**СЫРА́ҖЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Сыраҗ, тәңкә печән һ.б.ш.лар керә торган үләнчел үсемлекләр семьялыгы; *русчасы:* **норичниковые**. *Сыраҗчалар семьялыгына (Scrophulariaceae) бөтен җирдә үсә торган 250 ләп ыруг һәм 3000ләп төр керә ---.* Ботаника

**СЫРАЛЫК** *с.* **1.** 1) Сыра кайнату өчен билгеләнгән, шуңа җитәрлек булган

2) Сыра сатып алу өчен билгеләнгән, шуңа җитәрлек

**2.** *и. мәгъ.* Сыра сатып алу өчен җитәрлек акча. *[Егет]: «Кичә күп эчелгән, бабай, баш бик чатный, бер кружка сыралык кына булса да бирче. Төрмәдән котылган идем, условныйдан», – ди бу.* Н.Акмалов

**СЫРАХАНӘ** *и.* Сыра сатыла торган һәм сыра эчү өчен җиһазландырылган кибет, буфет. *Ул урамга чыгып, каршы яктагы сыраханәдән бер милиционер алып керде.* Х.Камалов. *Шуңа күрә, кояш төшлеккә җиткәнче, [Шамил Измайлов] ресторан, кафе, сыраханә, чәйханәләрнең байтагында булырга өлгерде.* З.Фәтхетдинов

**СЫРАЧЫ** *и.* 1) Сыра кайнатучы кеше. *Бактың исә, немец сырачылары, әйбәтрәк күбекләнеп торсын өчен, сырага кобальт хлориды өстәргә кирәк дип тапкан.* Ватаным Татарстан

2) Сыра сату эшендә эшләүче. *Ашчыларга, чәйханә тотучыларга, сугышчыларга, кымызчыларга, сырачыларга эш муеннан.* М.Әмирханов

**СЫРГА** *и.* 1) *диал.* Колак йомшагына тага торган асылма бизәнү әйбере, алка. *Чылтыр-чылтыр камышта Сыргам төште, яр-яр.* Җыр

2) Кәҗә, сарык ише хайваннарда тамак астында, әтәч һәм тавык ише кошларда томшык астында асылынып тора торган итләч үсенте

3) *бот.* Чук кебек асылынып тора торган оешма чәчәк. *Бакча эчендәге озын тирәкләрнең башлары күккә тиярлек. Алардан җиргә сыргалар коела.* Н.Сәфәрев

**СЫРГАВЫЛ** *и. монг. иск.* Кузгалмаслык, селкенмәслек итеп вертикаль рәвештә җиргә казып утыртылган бүрәнә; багана. *Тукталу урыны ерактан беленеп торсын өчен, биек калкулыкка озын багана – сыргавыл утыртып, аның башына байрак элеп куйганнар.* Р.Әхмәтьянов

**СЫРГАГӨЛ** *и. диал. бот.* Кырлыганчалар семьялыгыннан каршыдаш яфраклы, салынкы чәчәкле, җәй буе һәм көз башында чәчәк ата торган кечкенә куак яки ярымкуак; тамчыгөл, фуксия

**СЫРГАЛАНУ** I *ф.* 1) Уралу, бөтерелү, бормалану, боргалану. *Еланбалык башта бөгәрләнде, сыргаланды, аннары кызарынды-бүртенде, кычкырмакчы булып авызын ачты, кычкыра алмады, тавышы чыкмагач, башын бер як читкә салып тынып калды.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Кыланчыклану, назлану, кылану, чытлыклану. *Атын туктатты да Нурислам кызган туфракка чалкан ауды, шунда ук күктә бәләкәй генә ак болытка кунган Корбангали чәберчек булып сикергәли башлады. Әй боргалана Корбангали, әй сыргалана.* М.Кәрим

**Сыргаланып алу** Тиз генә сыргалану

**Сыргаланып йөрү** Һәрвакыт сыргалану

**СЫРГАЛАНУ** II *ф.* Сыргалар (*3 мәгъ.*) чыгару. --- *татар-кыпчак даласының кичә генә явып үткән яңгырлардан соң тагын да күпереп күтәрелгән үлән-үсемлек дөньясын: чәчкә аткан кәккүк башларын, зәңгәр күзле чыпчык чәчкәләрен һәм сыргаланган*

*бөтнек --- күргәч, күземә яшь типте.* Татарстан яшьләре

**СЫРГАНАК** *и. бот.* 1) Сырганакчалар семьялыгыннан әчкелтем сары җимеше ботакларына сырышып үсә торган куак (кайберләре чәнечкеле була); *русчасы:* **облепиха**. *Аерым авылларның урамнары ямь-яшел, бакчаларында алма, слива, сырганак, чия, миләш, шомырт агачлары, балан, карлыган, гөлҗимеш, кура җиләге куаклары үсә.* Ф.Гарипова

2) Шул куакның җимеше. *Сырганак җимешен беренче кар яугач, ягъни көннәр суыта төшкәч җыярга кирәк, ә моның өчен агач төбенә капчык киндере җәяләр һәм ботакларга җиңелчә генә сугалар.* Г.Гыйльманов. *Сырганак мае*

3) *диал.* Эт тигәнәге. *Миңа юлдаш булып, Тезләремә сырыла сырганаклар.* Р.Аймәтов

**СЫРГАНА́КЧАЛАР** *и. күпл.* Розачәчәклеләр рәтеннән көмешсу яфраклы, ярлы туфракларда үсә ала торган, сырганак, җидә һ.б.ш.ларны эченә алган агач һәм куак үсемлекләр семьялыгы

**СЫРГАНА́К ЧӘЧӘГЕ** *и. бот. диал.* Испәрәк

**СЫРЛАН** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан кытыршы төкчәләр белән капланган орлыклары киемгә, хайван йонына һ.б. ябышып, эләгеп иярә, сырыша торган берьеллык чүп үләне; *русчасы:* **липучка**. *Беткән анда әрем сабаклары, Мин яратмый торган сырланнар.* Н.Баян. *Быел чүп үләннәре шәп: сөтле билчән чәчкәгә бөреләнгән, каты билчәннең дә очында шәмәхә кәрзинчәләр, сырлан да чалбар балагына ябыша башлаган, кукчәчәк сабаклары озын, чәчәкләре керфекләнеп ачылырга тора.* Х.Камалов

**СЫРЛАНДЫРУ** *ф.* Сыр, эз, юл барлыкка китерү. *Җилләр исте су өстен сырландырып, Иркәм чәчен дулкындай тирбәлдереп.* М.Мөслим

**СЫРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сырлау**

2) Җыерчыклану. *Аның [Габделбәрнең] авыз тирәсе бер җыела төште, бер җәелеп китте, маңгае җыерчыкланып сырланды ---.* Э.Касыймов

3) *күч.* Назлану, ваклану, кыланчыклану. *Ашаганда, анысын яратмыйм, монысын яратмыйм, дип сырлану. Ялындырып сырлану*

**Сырлана бару** Бер-бер артлы сырлану. *Ләкин юк, Хәнәфи күңелендә әле һаман иң әүвәл адәмнәр әхвәле, авыллар язмышы тирән буразналар булып сырлана бара һәм... сырланачак та әле!* Э.Касыймов

**Сырлана башлау** Сырланырга тотыну

**Сырлана бирү** Бернәрсәгә карамыйча сырлануын дәвам итү

**Сырлана төшү** Беркадәр, бераз сырлану

**Сырланып алу** Кыска вакыт эчендә сырлану

**Сырланып бетү** Тәмам сырлану. *Хөрмәт, ихтирам белән ул тәбәнәк мәктәпне, пәке белән сырланып беткән кара партаны уеннан кичерде.* С.Рафиков

**Сырланып тору** Гел сырлану, хәзерге моментта сырлану

**Сырланып чыгу** Сырланган хәлгә килү. *Аның ирене әллә ике, әллә өч катлы булып сырланып чыкты.* Г.Бәширов

**СЫРЛА́П-БИЗӘП** *рәв.* Сырлы итеп, бизәү элементлары кертеп. *Сырлап-бизәп салынган йорт*

**СЫРЛА́У** *ф.* 1) Сырлар ясау. *Пәке белән таяк сырлау*

2) Сырлар, җыерчыклар хасил итү. *Аның маңгаен, күз төпләрен, битләрен сырлаган эре җыерчыклары караңгыланып тирәнәйгәннәр, борын тишекләре киерелгән, шаулатып сулыш алганы ишетелә.* Ф.Садриев

3) *күч.* Сырлы итеп бизәкләү; гадәти сызыкларга боргалап бизәү элементлары кертү. *Хатынның чигәсендә, мул булып, иртәнге чык тамчыларын хәтерләткән тир бөртекләре җемелдәшә, йөзен тир чишмәләре сырлаган иде.* Ә.Гаффар. *[Әнием] Алтын белән сырлаган агач савытка сөт тә сала.* Н.Дәүли

4) *күч.* Тиз-тиз язу; гадәттә вак кына итеп язу. *Шулай да улниндидер кәгазьләр сырлап тутырды да Рушанның әнисенә кырыс кына итеп әйтеп куйды ---.* Р.Мирхәйдәров. *Лекция тыңлап, конспект сырлап баш ватмады: иркенләп күңел ачып йөрде.* Х.Ибраһим. *Матур итеп русча язылган беркетмәгә җыенда катнашкан 159 кеше имзасын сырлый.* Т.Нәҗмиев

5) *күч.* Образлы итеп яисә артык сөйләү турында. *Сырлап тормыйча гына әйтү*

**Сырлап алу** Тиз генә сырлау

**Сырлап ату** Тиз генә яки аннан-моннан сырлау

**Сырлап бетерү** Барысын да сырлау, сырлауны тәмамлау

**Сырлап кую** Тиз арада сырлау. *Аның читендә [почта кәгазендә] контрразведка башлыгы Кузьмин сырлап куйган кыска резолюция генә бар иде: «Тикшерүне капитан Т.Ә. Мулюковка тапшырырга».* З.Фәтхетдинов

**Сырлап чыгу** Һәрберсен, башыннан ахырына кадәр сырлау

**Сырлый бару** Бер-бер артлы барысын да сырлау

**Сырлый башлау** Сырларга тотыну

**Сырлый бирү** Бернәрсәгә карамыйча сырлауны дәвам итү

**Сырлый төшү** Беркадәр, бераз сырлау; тагын да сырлау

**СЫРЛЫ** I *с.* Сыр (I) ясалган, сырлары булган. *Бераздан Хәниф абзый сискәнеп киткәндәй булды. Кинәт кенә нәрсәдер исенә төшкәндәй, кулымнан әлеге сырлы тактаны алды, аны саклык белән генә өстәл астына яшереп куйды, аннары тагын каршыма килеп утырды.* Г.Гыйльманов. *Авыл өенеке кебек кечкенә ике тәрәзәсенә юан, сырлы тимер чыбыктан рәшәткә ясап куелган.* М.Маликова. *Каенның яфрак кырые пычкы теше кебек сырлы була.* К.Латыйпов

**СЫРЛЫ** II *с.* Эченә сыр кушылган; сыр белән бергә ясалган. *Төшке ашка кадәр сырлы бутерброд һәм нинди дә булса җиләк-җимеш капкаласалар яхшы булачак.* Ватаным Татарстан

**СЫРЛЫГУ** *ф.* Нык якын килеп терәлү; сарылу, сыену. *Ул әкият сөйләгәндә, без куркуыбыздан бер-беребезгә сырлыгабыз.* М.Гафури

**СЫРЛЫ́-МЫРЛЫ** *с.* Төрле бизәкләре, сырлары булган. *Ул мебельләре! Безнеке шикелле сырлы-мырлы тузан оясы түгел, бар да бер очтан, бар да импорт, полированный, күзгә кебек ялт-йолт итеп кенә тора.* Г.Әпсәләмов

**СЫРЛЫ́-СЫРЛЫ** *с.* 1) Сырлары (I) булган. *Әнвәр бүлмәгә соклана иде. Җыйнак кына, бер тәрәзәсе бар, шуның астында сырлы-сырлы батарея тезелгән.* Х.Камалов

2) *күч.* Бизәкле, нәкышьләре күп һәм төрле-төрле итеп төшерелгән. *Миңа аның әнә шулай олы гәүдәле, зур кеше булуы да, беләкләренең, бармак юанлыгы тамырлардан үрелгән шикелле, ничектер үзалдына сырлы-сырлы булып торуы да бик ошый.* Г.Бәширов. *Озын-озын өстәлләрдә ниләр генә юк, муллык: сирәк очрый торган кыйбат балыклар, колбасалар, чит илләрдән кайтарткан шәраблар, сырлы-сырлы аракы шешәләре ---.* Р.Батулла

**СЫРМА** *с.* **1.** Сырган, сырып тегелгән. *Туткыл йөзле Борһан, өстендәге сырма пиджак җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганып, кызган озынча тимерләрне чүкеп торганда, алачыкка Гыймазов килеп керде.* С.Рафиков. *– Ә-ә, – диде Денис һәм күн сырма чабуы белән авызын сөртеп алды.* М.Хәбибуллин. *Әнисе, сырма бишмәтен элгечкә элүгә, улы янына килде.* Р.Ишморатова

**2.** *и. мәгъ.* Сырып тегелгән, кыска җылы өс киеме. *[Хәнәфи] Кабаланып, өстеннән сырмасын, башыннан бүреген салды, әмма аларны элгечкә элеп тормыйча, алгы өйнең ишек төбе сәкесенә генә атты.* Э.Касыймов

**СЫРМАВЫК** *и. бот.* Мареначалар семьялыгыннан сабаклары дүрт кырлы, зәңгәрсу чәчәкле берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **ясменник**. *Районның үлән капламында сәрдә һәм исле сырмавык өстенлек итә*

**СЫРМАК** *и. диал.* Сырып, билләп тегелгән бишмәт

**СЫРМАЛЫ** *с.* 1) Сырып тегелгән, сырган. *Рәфис эче сырмалы күн курткасын гына эләктерде дә Мәхмүт янына йөгереп чыкты.* А.Вергазов

2) Сырма кигән. *Бераздан өй эче сырмалы, йон оеклы, яулыкларын арттан я алдан бәйләгән хатыннар, кызлар, брезент кожан кигән малай-шалай һәм ир-ат белән тулды.* А.Расих

**СЫ́РНИК** *и. рус* Эремчеккә тәмләткеч катнаштырып ясалган калын коймак формасындагы ашамлык. *Тик башта миңа сырниклар әзерләгез. Икенче көн инде шуны үтереп ашыйсым килә...* Кызыл таң

**СЫРОК** *и. рус* Ваниль, йөзем, шикәр һ.б.ш. кушылган эремчектән гыйбарәт татлы кондитер эшләнмәсе. *Күптән түгел телевизордан, кибеттән берничә сырок алып, милиция бүлмәсенә кертелгән бер әби турында сөйләделәр.* Шәһри Казан

**СЫРПАЛАНУ** *ф.* 1) Янда, аяк астында ышкыла-ышкыла уралу. *Йомшак кулы белән болын җиле Песи баласыдай сырпаланып, Иркәләнеп сарыла тезләргә.* Ә.Сыйтдикова

2) *күч.* Иркәләнү, назлану. *Ә инде шактый зур кыз булып үсеп килгән Язгөлеме, әни назын эзләптерме, һаман Сәнифәгә сырпаланды.* Э.Шәрифуллина

3) *күч.* Куштанлану, ялагайлану, ярарга тырышу; әрсезләнеп иркәләнү, назлану. *– Тимирчик, – дип, шундук сырпаланырга керешә Оксана.* Р.Мөхәммәдиев

**Сырпалана башлау** Сырпаланырга тотыну. *Юаш, иркә Актырнак Сарбаев (Ифрат аны шулай атый иде) шунда ук койрыгын болгап, чак кына ишетелерлек шыңшып сырпалана башлады.* А.Расих

**Сырпалана бирү** Бернәрсәгә карамастан сырпалану, сырпалануын дәвам итү

**Сырпалана төшү** Беркадәр, бераз сырпалану

**Сырпаланып алу** Бераз сырпалану. *Ягымлы сүзләрен кызганмый сырпаланып алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

**Сырпаланып йөрү** Һәрвакыт сырпалану. *Фәләх тирәсендә Гасимәнең чамадан тыш сырпаланып йөрүен һич кенә өнәмәгәнлеге әллә кайдан күренеп тора, һәм ул аны яшерүне кирәк тә санамый, юри шулай дорфа кылана иде.* В.Нуруллин

**Сырпаланып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер сырпалану. *Илдар күп сөйләшми, эшне коры тота. Янында озаграк сырпаланып тора башласаң: – Булды. Бар, эшеңне кара, – ди.* Э.Шәрифуллина

**СЫРТ** *и.* **1.** 1) Хайваннарда: арка. *Күзләребез белән тагын чабыш атларының күкрәк тирәләрен, сырт өсләрен капшый башладык.* Г.Бәширов. *Камчының иң утлылары койрыксыз бүре сыртына төшкән.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Кешедә арка. *Кем иптәшләренә салына, кайсы ишкәкче эленке-салынкы ишә, камчы шуның сыртына төшә.* М.Хәбибуллин. *Бу юлы да, авылга кайтып, барча халыкның акаеп караганын сыртым белән тоеп тордым.* К.Миңлебаев

3) Кулның, бармакның уч төбенә каршы ягы; бияләй, перчатка кебек нәрсәләрнең шул турысы. *Вакыты-вакыты белән ул, сулышы кысылгандай, авыр сулап куя; күз яшьләрен кул сырты белән сөртеп ала.* С.Сабиров. *Ялт итеп миңа карап алды да яртылаш салынып төшкән бияләй сырты белән борынын сөртеп куйды.* Ә.Дусайлы

4) Кисә-чаба торган коралның үткен йөзенә, кискеченә каршы, кире ягы. *Чүкече белән пычак сыртына сугып кыйный торгач, зынҗыры шактый киселде, әмма өзелеп үк чыкмады.* Ж.Рәхимов. *Миңлебай, кылыч сырты белән маңгаена, колак төпләренә һәм муен тамырына суккалап, бүрене тиз-тиз генә үтереп ташлады.* Н.Яһудин

5) Бер буйга сузылган агачлар, таулар һ.б.ш.ның түбәләренең тезмәсе. *Менә шул тау сыртының берәрсе ишелеп төшсә яки анда каты җир тетрәү була калса, «цунами» дулкыны куба.* Э.Касыймов. *Чөнки өстәгеләр, тагын бер бәйләм чамасы күтәрелсәләр, кыяның безгә күренми торган сыртына чыгачаклар.* А.Хәсәнов. // Буйга сузылган калку җир. *Авылдан ике километр ераклыкта, сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә.* Ә.Еники

6) Дулкынның иң югары өлеше, түбәсе. *Алар атылган уктай кинәт кенә түбән ташланалар да, вак дулкыннар сыртында сикерешеп уйнаган бәләкәй балыкларны яисә пароходтан пассажирлар ыргыткан ипи кисәкләрен эләктереп, яңадан аяз күккә күтәреләләр.* М.Галәү. *Дулкын озынлыгы – ике дулкын сырты арасы.* Башлангыч география курсы

**2.** *с. мәгъ.* Сырт (*5 мәгъ.*) рәвешендәге, калкып-күтәрелеп тора торган.

*Басуның сырт урыннары инде ачылып беткән.* Ф.Сәйфи-Казанлы

◊ **Сырт бирү** 1) Арка белән борылу. *Эш кушсаң, сыртын гына бирә;* 2) Җиңелү, сынату. **Сырт кабарту** 1) Йоннарын тырпайтып, сыртын дугаландырып, ачулы кыяфәткә керү, каршы тору (песи, эт һ.б.ш.). *Мин, әүвәлгечә шаяртып, аның күңелен күтәрергә тырышып карасам, сыртын кабарткан мәче сыман пырылдый, тиргәшә башлый, авыр сүз әйтә.* Л.Ихсанова; 2) Ачу белән каршы килү, килешмәүчәнлек, ризасызлык күрсәтү. *Урал якларында да контрреволюция дулкыны Совет властена каршы сырт кабартты.* З.Фәтхетдинов. *Кызының клубтан кайтып кергәч тә тырт-пырт йөрүе, сырт кабартулары аңа һич ошамаган, тик ачыну хисе, шик-шөбһә генә кузгаткан иде ---.* Э.Касыймов. **Сырт каезлау** Кыйнау, тукмау, дөмбәсләү. *Сыртын чыбыркы белән каезлау.* **Сырт кую** *к.* **сырт бирү** (*1 мәгъ.*). *Каһәр генә яусын, дөньясы гел сыртын куя, бернәрсә дә җиңел генә, көрәшсез генә бирелми аңа.* Н.Гыйматдинова. **Сырт сукмагы белән маташу** Ялган сөйләү, намус кушканча эшләмәү. **Сырт сынса да сер бирмәү** *к.* **сырт сынса да сынатмау**. **Сырт сынса да сынатмау** Ничек кенә кыен булса да, хәлеңне сиздермәү, сер бирмәү. **Сырт яру** *к.* **сырт каезлау**. **Сыртны җиргә тидермәү** 1) Уңайсыз хәлгә калмау; 2) Хәлеңне сиздермәү, сер бирмәү. **Сыртын сындыру** 1) Көрәштә көндәшен җиңү; 2) Көрәштә, сугышта һ.б.ш. дошманны тәмам тар-мар итү

**СЫРТЛАН** *и. зоол.* Җылы якларда яши, башлыча үләксә белән туклана торган яллы имезүче ерткыч хайван; *русчасы:* **гиена**. *Үлем белән байтак тапкыр инде Күзгә-күз без туры килештек. Ул ыржаеп карап торды миңа, Читлектәге сыртлан шикелле.* Х.Туфан. *Аның артыннан үләксә калдыгы эзләгән сыртлан кебек бик озак иснәнеп барырга туры килде аңа.* В.Имамов

**СЫРТЛЫК** *и.* 1) Сырт җир, калку җир. *Казаннан килгәндә, сыртлык итәгендә утырганга күрә, ул (авыл) үзенә тәмам барып җитмичә күзгә ташланмый.* Г.Тавлин

2) *диал.* Ыңгырчак астына куела торган йомшак әйбер, ыңгырчак киезе. *Сыртлыкларны җитәрлек хәзерләргә кирәк*

**СЫ́РТ СӨЯГЕ** *и. анат. диал.* Умырткалык. *Ә эшкә килгәндә сырт сөяге һаман йомшак шул, ныклык җитми, ныклык!..* А.Гыйләҗев. *Алда авыр кыш, авыр кыш артыннан адәмнәрнең билен, сырт сөяген сындырып язы килер.* Я.Зәнкиев

**СЫРУ** I *ф.* 1) Ике катлы тукыма арасына йон, мамык һ.б.ш.ны салып, шакмаклап яки буй-буй эзләр ясап тегү. *Көннәр җылынуга да карамастан, өстенә арка җылысы, сырган чалбар кигән, башын арзанлы мутон бүрек белән каплаган абзый Хәләфне яткан урыныннан тартып торгызды...* Х.Ибраһим

2) Төрле матур бизәкләр, сырлар белән бизәп тегү. *Читек сыру. Кәләпүш сыру. Түбәтәйне сәйлән белән сыру*

3) *күч.* Кат-кат ямап бетерү, күп итеп ямау салу

**Сыра башлау** Сырырга тотыну

**Сырып бетерү** Сыру эшен тәмамлау

**Сырып кую** Тиз генә сырып, әзер хәлгә китерү; алдан сыру

**Сырып утыру** *сөйл.* Хәзерге моментта сыру эше белән мәшгуль булу

**Сырып чыгу** Билгеле бер вакыт эчендә сыру эшен башкару

**СЫРУ** II *ф.* 1) Күп булып иярү, ябышу (вак бөртекле нәрсәләр тур.). *Керфекләргә бәс сыра, борын очларын, битләрне кызарта.* Р.Хафизова. *Тирәюньнәрен кырмыскалар сырып алган түмгәк төбендә җиләк чәчәге балкып утыра.* Ф.Шәфигуллин. *Ул, умартачыны кортлар сырып алу белән, куркып читкә йөгерә башлады.* Ф.Яруллин

2) Бер урында бик күп булып, тезелеп яки өсте-өстенә урнашу. *Килеп кергәч тә, күз стеналарны сырып алган китапларга төшә.* К.Тимбикова. *Шомыртны чәчәк сыру. Сарыкны тигәнәк сыру*

3) *күч.* Берәр кеше яки нәрсә дә булса янына җыелу, аны чолгап алу. *Урамга чыгу белән, үземне карт-карчык, бала-чага сырып алды.* А.Кутуй. *Кайтып туктауга, аны мал караучылар сырып алды.* Н.Әхмәдиев. *Әнә күпме кеше җыелган. Чыннан да, сыерны сырып алганнар, берәү инде сатулаша да башлаган.* Р.Кәрами

**Сыра башлау** Сырырга тотыну

**Сырып алу** Тоташ сыру. *Минә кечкенә генә ялан, тәбәнәк кенә куакларын сырып алган кара җимешләр әлмисактан бирле шуларга тагылган кебек тик торалар.* Г.Исхакый. *Көрлекләре, тазалыклары белән карарга соклангыч чәнечкеле сабакларны сары-сары чәчәкләр сырып алды, чәчәк төпләрендә бодай бөртеге кадәр генә кыярлар күренде.* М.Әмир

**Сырып бетерү** Бөтенләй, тоташ сыру

**Сырып тору** Даими рәвештә, һәрвакыт сыру

**СЫРУЛЫ** *с.* Сырып эшләнгән, сырылган. *Аягында Казанның әйбәт читек-кәвеше, башында яңа колакчын, якасы бишмәттән кайтарылып төшкән ак күлмәк, эче-тышы сырулы, эре чуар бизәкле яңа көпе, билдә кәмәр: хәзер Азымбай, чыннан да, теләгән илгә би булып сайлана алырлык хөрмәтле бер аксакал иде.* Г.Ибраһимов

**СЫРХА́У** I *с. фар.* **1.** Авыру, чирле. *Үзең сырхау, эшләр кешең юк.* Г.Бәширов. *Сырхау кешене үлемнән коткарыр өчен, кырык «Ясин» чыгарырга кирәк.* Н.Сәфәрев. *[Мөршидә:] Шулай инде, сырхау, авыру кеше беркемгә дә кирәк түгел.* Х.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Чир, хаста, авыру. *Сырхавы шулкадәр дә каты булган ки, һәртөрле табиблар вә им-томчылар бернинди дәва да таба алмаганнар.* Ф.Яхин. *Нервы сырхавы кузгалган Кадыйрның авыр, газаплы өне әкрен-әкрен менә шулай бастырулы авыр төшкә ялганып китте.* И.Низамов. *Рәхмәтулла йортына чакыру килгәч, яңагын иске тире бияләй белән урады да, сырхауга сабышып, урын өстендә ухылдап ятты.* Я.Зәнкиев

**СЫРХА́У** II *ф.* 1) Авыру, чирләү

2) Авырту, сызлау. *Кай җиреңә сырхый, балам?* К.Нәҗми

**Сырхап алу** Берара сырхау

**Сырхап киту** Көтмәгәндә сырхау

**Сырхап тору** Әле хәзер сырхау. *Сырхап тора: ике көн инде тәне кызышып, башы авыртып йөри.* Я.Зәнкиев

**СЫРХАУЛА́У** *ф.* Чирләү, авыру. *Алар булган балаларын сырхаулаган, үлем алдыннан хисаплап, көннәрен, төннәрен йокысыз кичерделәр.* Г.Исхакый. *Иван Фёдорович белән май заводы директоры арасында булган сөйләшүдән соң, директорның өендә сырхаулап ятуы һәм әлеге приказдан хәбәрсез булганлыгы ачыкланды.* Р.Кәрами

**Сырхаулап алу** Кыска вакыт эчендә сырхаулаган хәл кичерү. *Әнисе картая бара, сырхаулап та ала.* Ш.Галиев

**Сырхаулап бетү** Эш сырхаулауга ук барып җитү. *Ябыгып, сырхаулап беттем, адәм карарлык кыяфәтем калмады, малай.* Р.Төхфәтуллин

**Сырхаулап йөрү** Күптәннән бирле сырхаулау

**Сырхаулап китү** Кинәт сырхаулау. *Институтны тәмамлаган елны Мидхәтнең әнисе сыер савуны ташлады, әллә шул ярамады, сырхаулап китте, больницага ятты.* М.Хәбибуллин

**Сырхаулап тору** Әле, хәзер сырхаулау, бераз сырхаулау; әледән-әле. *Түткәң сырхаулап тора, яңа бал, дип җанга тия.* М.Хәбибуллин. *Көндәшем Фатыйма бикә килмәде, сырхаулап тора, имеш.* М.Әмирханов

**СЫРХАУЛЫ** *с. к.* **сырхау** I (*1 мәгъ.*). *Сырхаулы әниеңә барына да җитешергә бер генә дә җиңел түгел шул.* Э.Касыймов. *Әни кисәк кенә биреште, берничә айда сырхаулы, бөкрәйгән карчыкка әйләнде дә калды.* Г.Госман

**СЫРХАУЛЫК** *и.* Авыру, чир, сырхау булу. *Юксынганда газиз әнкәемне, Сырхаулыкны тоймыйм, сизмимен. Авыр чакта рәсеменә карап Киңәшләшәм, ярдәм сорыймын.* Ф.Гыйльфан

**СЫРХАУХАНӘ** *и. фар.* Хастаханә, поликлиника, диспансер кебек медицина ярдәме күрсәтү, дәвалау учреждениеләренең гомуми исеме. *Шул вакыт яныбызга ахылдап диспетчер кыз йөгереп керде: «--- Үзе сырхауханәдә, ди, машинасы юл буенда калган!»* Ф.Галиев. *Сырхауханә коридорында шәфкать туташлары көлешә.* Т.Миңнуллин

**СЫРЧЫ** *и.* Сыр (II) ясау остасы, сыр кайнату белгече. *Сырчы шөгыле*

**СЫРЫЛУ** I *ф. төш. юн. к.* **сыру** I

**СЫРЫЛУ** II *ф.* 1) Сырышу, күп булып ябышу. *Көньяктан искән җил җылылык алып килә, һава сизелерлек йомшарган, бу җепшек буран җиргә көпшәк кар түшәгән, читән, коймалар юеш ак мамык белән сырылган иде.* С.Рафиков. *Вак балыклар, сырылып, Төнбоекны уйната.* Ш.Гаделша

2) *күч.* Янда булырга тырышу, әрсезләнеп ияргү, җыелу. *Хәйдәрнең як-ягына сырылып, өенә кадәр озатып бару балалар өчен зур куаныч була иде.* Г.Бәширов. *Ул фаҗигале таңда Төн кызы, гадәттәгечә анасы кочагына сыенып, таулар артындагы тирән чокырларга-мәгарәләргә ял итәргә китми, япадан-ялгыз далада калып томанга әверелә һәм үзенең сөт кебек ак тәне белән Сары арка өстенә сырылып, аны кояштан яшерә.* И.Салахов

**Сырыла бару** Акрынлап сырылу

**Сырыла башлау** Сырылырга тотыну

**Сырыла төшү** Беркадәр сырылу

**Сырылып тору** Сырылган хәлдә булу

**СЫРЫЛУЧАН** *с.* Сырыла, ябыша торган

**СЫРЫНТЫ** *и.* 1) Сырт сыман булып сырышып өелгән кар; дулкын сырты сыманрак салган көрт. *Кыш буе салган бу кар сырынтылары әле иртән, мәктәпкә килгәндә, шактый биек иде, хәзер сизелерлек юкарган.* Ф.Садриев. *Кыектан шөпшә оясы кадәр кар сырынтысы кубарып, кояшка таба сибеп җибәрде: «Яз житкәч, бөртеге дә калмас әле...»* Л.Зөлкарнәй

2) Өскә, киемгә күп булып сырышып ябышкан нәрсәләр (кар, мамык һ.б.ш.). *Әмма тамчылар шулкадәр кайнар иде ки, алар егетнең тәнен көйдереп алды, һәм Зөфәрнең күз алларын томалап торган ак томан да, әле генә бөтен дөньяны баскан кар сырынтылары да таралып юкка чыкты.* Ж.Дәрзаман

**СЫРЫНТЫЛАП** *рәв.* Сырынтылар (*1 мәгъ.*) рәвешендә. *Сырынтылап салган ул кар май азакларына чаклы эреми.* М.Хәбибуллин

**СЫРЫНУ** *ф.* 1) Күп булып ябышу, сыру (сырлан, кар һ.б.ш. тур.)

2) *күч.* Берәүгә елышу, куштанлану, аның янында булырга тырышу. *Сырынмасын аңа сыйнфый дошман.* Ә.Баян

**Сырына башлау** Сырынырга тотыну

**Сырына бару** Акрынлап, бер-бер артлы сырыну

**Сырына төшү** Беркадәр сырыну

**СЫРЫШКАК** *с.* Күп итеп ябыша, сырыша торган

**СЫРЫШМА** *с.* Күп итеп яки тоташ яфрагы-сабагы белән ябыша торган (үсемлек тур.). *Сырышма сабак*

**СЫРЫШУ** *ф.* 1) Сырып алу, күп булып ябышу; ияргү (мамык, сырлан һ.б.ш. тур.). *Кыш көне кар бүрәнәгә сырышып яуса, җәй яңгырлы килер.* Сынамыш. *Су тамчылары менә шул кисәкчәләргә сырышалар да инде.* Дөньяда ниләр бар

2) *күч.* Берәр җиргә, әйбер яки кеше янына күп булып җыелу. *Эшелон башлыгыннан аңкыган хушбуй исе тоткыннарның борынына бәрелде. Тоткыннар ишеккә табарак сырыштылар.* И.Туктар. *Өстәвенә, ул пароходларга чебен кебек сырышкан фәкыйрь-фөкара, баржадагы бу дүрт бәхетсездән көлеп, үз хәленең авырлыгын онытa иде бугай.* З.Фәтхетдинов. *...Вакыт үтү белән каралып беткән, читән белән уратылган йортлар тәртипсез рәвештә тауга сырышканнар.* И.Низамов

3) *күч.* Берәр кеше янына сыену, елышу; әрсезләнеп ияргү, куштанлану. *Лапастагы Актүш каядыр югалып торган хуҗасының аякларына килеп сырышты, бер мәртәбә аның битен ялап алырга да өлгерде.* С.Рафиков.

**Сырыша бару** Әкренләп сырышу

**Сырыша башлау** Сырышырга тотыну

**Сырыша төшү** Бераз сырышу

**Сырышып бетү** Барысы да сырышу

**Сырышып тору** Хәзерге вакытта сырышу

**СЫТКЫ** *и.* Тирегә, тәнгә чыга торган каты башлы бетчә, вак сызлавык. *Тире астында каты төер сыткы бик ачык кулга беленеп тора.* Ә.Еники. *Саҗидәкәйнең сөйкемле, чибәр йөзен тагы да чибәрләтеп, матур гына үскән*

*борынының нәкъ очында тары ярмасы зурлыгында гына, уртасы аз гына саргылт, читләре кып-кызыл сыткы чыгып, караган кешенең күзенә чекрәеп бәрелеп тора!..* Г.Иделле

◊ **Сыткы сагызы** Бәйләнеп, туйдырып йөрүчән, теңкәгә тиючән кеше турында. *[Мортый:] Җитәр, энем Сиражи, алама кешенең теле ачы, ябага тайның бете ачы, дигәндәй, бер нәрсә булса, сыткы сагызы кебек кешегә ябышасың.* Т.Гыйззәт. *Хәйрул соңгы вакытта тәмам сыткы сагызына әйләнгән булган: өйләнешәбез, дип ябышыпмы-ябышкан.* И.Низамов. *Билгеле: «Хатыны түгел, ние түгел, дигәндәй, бигрәк инде сыткы сагызы кебек ябышты», – дип, Хәбирәнең ул кыланышларын бик үк килештереп бетермәүчеләр дә булды.* М.Хәсәнов

**СЫТКЫЛА́У** *ф.* Кемнең дә булса тәненә күп итеп сыткылар чыгу, сыткы басу, бетчәләү

**Сыткылап бетү** Тоташ сыткылау

**Сыткылый башлау** Күпләп сыткылар чыгарга тотыну

**СЫТКЫЛЫ** *с.* Сыткылары булган, сыткы баскан, сыткылаган, бетчәле. *Шул җир бәрабәренә газиз хатыны Наилә сыткылы танау, камыт аяк Изил Латыйпов белән йоклап кайткан икән, Җир шарын үкчәләре белән тибәтибә «Мебель» кибетенә килеп кергән Нәҗипне бүгеннән тозакка төшерә алмассыз!* А.Гыйләҗев. *Әнә маңгай чәче ике уем булып эчкә кергән, зур борынлы, күзлекле Шәйдуллин, әнә сыткылы битле, эчкә баткан астыртын карашын күзлек астына яшергән Азюков, әнә акай бәбәкле ертлач Хатыев…* Х.Камалов

**СЫТУ** *ф.* 1) Тышчалы (җиләкҗимеш), кабыклы (йомырка) нәрсәләрнең, кысып, эчендәге сыекчасын агызып чыгару, изү. *Әледән-әле әнисенә шалтыратып, сорашып кына тора: пилмән камырына ничә күкәй сытарга, пылауны ничә стакан суда кайнатырга, төче бәлеш камырына күпме сода салырга?* Е.Әмирхан

2) Шеш, чуан, сыткы һ.б.ш.ларның, бармак белән кысып-басып, эчендәге үлеген, үзәген чыгару, сары суын агызу. *Әнисе [кызының борын очындагы] сыткыны сытарга, эченнән сарысын чыгарырга киңәш бирде.* Г.Иделле. *Көнем бетчә сыту белән башлана, шуның белән тәмамлана.* Безнең гәҗит

3) Басып, таптап яки бүтәнчә кысып үтерү, изү. *Инде баеп беттем дигәндә генә аларны кандаладай сыталар.* Ф.Дәүләтбаев. *Шәһәр җитәкчелеге, урамда күренгән тараканнарны сытып үтерергә, дигән белдерү бастырган, чөнки аларның әшәке чир таратулары бар икән.* Татарстан яшьләре

4) Берәр нәрсәнең өстенә басып, таптап, авыр әйбер куеп яки бүтәнчә яньчү, изү. *Туплар гөрселди, бөтен нәрсәне сытып, җимереп, үкерә-үкерә танклар йөри.* Г.Бәширов

5) *күч.* Җиңеп тар-мар итү; буйсындыру. *Авыр коралланган татар атлыларының һөҗүме шулкадәр көтелмәгәндә булды, алар дошманның ике канаттагы полкларын сытып уздылар, исән калганнарын таратып бетерделәр.* С.Шәмси. *Кайчан гына сытарлар фашист аждаһасын?* Р.Ишморатова

6) *күч.* Авыртудан, җирәнүдән, килешмәүдән табигый булмаган төскыяфәт бирү, бозу (йөзне, чырайны). *Фәрхетдин башта чыраен гына сытты, ә инде маёвкаданиләр буласын ишеткәч, тәмам куркуга төште.* А.Расих. *Шагыйрьнең йөзе сытылды.* З.Мәхмүди

**Сыта башлау** Сытарга тотыну. *Кияве, бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый.* Ә.Еники

**Сыта төшү** Беркадәр сыту; ныграк сыту. *– Ачуны чыгарып, сару кайнатып йөрмәсәңче, агайне! – диде егетләрнең киң җилкәлесе, болай да чытык чырайларын тагын да сыта төшеп.* А.Хәсәнов

**Сытып бетерү** Бөтенесен дә сыту. *Мәхәлләбездә бер томана кеше, кызына чәчәк чыккач, ярасы кычыткан саен кашый биреп, баласының күз тирәсендәге эреннәрен сытып бетергән.* Н.Сафәрев

**Сытып кую** Бер момент эчендә сыту. *Иван Кириллович, теше сызлый башлагандай, кинәт чыраен сытып куйды.* С.Сабиров. *– Киенегез! – диде ул, ни өчендер «сез»гә күчеп. Язучы чыраен сытып куйды.* М.Кәбиров

**Сытып ташлау** Тиз арада сыту. *Без күп, сезне сытып ташларбыз.* М.Хәбибуллин. *Кирлемән курка калды. Аю теләсә аны хәзер сытып ташлый ала иде.* Р.Хафизова

**Сытып чыгу** Тоташтан барысын да сыту. *Берничә секунд эчендә ул утыргычка сикереп менде һәм, җирдә яткан капотларны трактор тәгәрмәче сытып чыга инде дигәндә генә, тракторны туктатып өлгерде.* М.Хәбибуллин

**СЫТЫК** *с.* **1.** 1) Сытылган; яньчелгән, изелгән. *Ләкин, ырымның хикмәтен сизенгәндәй, Регина әби símezенең сытык йомыркага исе китмәде, мыегына чыланганын ялмаштырды да, тәпиләрен яшереп, коелган ылыс өстенә менеп ятты, колак очына тиеп торган кыяк үләнне өзеп чәйнәде.* К.Кәримов. *Сытык лимон*

2) *күч.* Ямьсез, ачулы сыман, ягымсыз, күңелсез, бозык (каш-күз, йөз, чырай тур.). *Төмсә чырайлы Нәүширван абзый беркайчан да әйбәт димәс, гел кирегә сукалар, эче авырткан кеше сыман, чырае сытык булыр.* М.Галиев. *Фил сөяген хәтерләткән тиреле чибәр йөзе сытык, борчулы, кайгылы.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Еларга гына торучы, шыңшык, елак. *Җаным сөйми елак, сытык егетләрне, Яратам мин шаярганны, көлгәннәрне.* Р.Вәлиев. *Әле яңа гына ир өендә тора башлаган һәм андагы тәртипләргә күнегеп китә алмаган җиде-сигез яшьлек сытык малайларның шулай анасы итәгe янында балавыз сыгып торуын күрсәләр, өлкәннәр шундук ыгы-зыгы, шау-шу куптаралар ---.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* Табигый рәвештә түгел, теләмичә, кыяфәт чыгарып кына. *Тизтиз машинага кереп чумган малайлар янына бүктәрләрне, кая куйсаң да төртеп-чыгып торган хәсрәт велосипедны кертеп урнаштыргач, Наилә, итәген җыештырып, алар янына кысылырга әзерләнгәндә, кәтәнә, сытык елмаеп, аны туктатты.* А.Гыйләҗев

**СЫТЫКЛЫК** *и.* 1) Сытылган булу, изелгәнлек

2) *күч.* Күңелсезлек, караңгы чырайлылык. *Тафтилов чыраен сытып күзәтте, сытыклыгы һич бетмәде.* Х.Камалов

**СЫТЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **сыту**. *Бөртекләрнең ярылуы, сытылуы һәм башка төрле механик ватылулар сыйфат югалтуга китерәләр.* Урып җыю машиналары

2) Кысылып-басылып, тишелеп, эчендәге сыегы, суы, үлеге һ.б.ш. агып чыгу. *[Зифа:] Уларым кабара язды бугай. Ай --- кара әле, Сылу, чынлап та кабарып чыккан. [Сылу:] Абау, мескен, сытылыр да әчетер инде.* М.Фәйзи. *Дөрес, җылылык арткан (демократия үскән) саен, чуаннар да сытыла, яман ис тә тарала башлады.* И.Әмирхан

3) Тапталып-кысылып яньчелү; басылып-кысылып изелү. *Аның әйләнә-тирәсендә сытылган, яньчелгән вагоннар, бөгәрләнеп килгән рельслар тырпаеп тора иде.* Г.Бәширов

4) *күч.* Авырту, җирәнү, килешмәүне белдереп ямьсезләнү, табигый төсен югалту (йөз тур.). *Газинур Сәлимнең чырае сытылуын һәм бүре шикелле каравын бик тиз сизеп алды.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Елау, кәефсезләнү, канәгатьсезләнү башлау. *– Әни янына кайтам, – диде малай тычкан кебек чыелдап, әмма элеккечә сытылып еламады, күрәсең, төне буе елый-елый яше кипкән иде.* Н.Гыйматдинова

**Сытыла бару** Тоташтан, рәттән сытылу

**Сытыла башлау** Сытылырга тотыну

**Сытыла төшү** Бераз сытылу

**Сытылып алу** Тиз арада сытылу. *Тәрәзәгә тагын хатынның чырае сытылып алды.* Р.Зәйдулла

**Сытылып бетү** Бөтенесе дә сытылу

**Сытылып китү** Кинәт кенә сытылу. *Йөрәге әрнүдән Ильясның чырае сытылып китте: «Их, Иза, белмисең шул син минем хәлләрне!»* И.Низамов

**Сытылып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер сытылу

**Сытылып чыгу** Бөтенләй, тәмам сытылу

**СЫХМАН** *и.* Чуваш халкы кия торган җилән сыман озын кием; чикмән. *Карчык-корчык вак шакмаклы көрән шәльяулык, озын чуклы кара шәл, итәгенә һәм җиң очларына яшел тасма теккән кара сыхман кигән.* Р.Кәрами. *Әгәр аңарда шул серле кыл булса, Андрюша әтисенең сыхманы астында ятар идеме соң!* К.Латыйпов

**СЫЧКАН** *и. иск. диал.* Тычкан. *Мәгәр ул коеның эчендә сычкан туп-тулы иде, коега салынган адәмне шул сәгать ашап бетерерләр иде.* К.Насыйри. *Шул мәлдә Нигъмәтулланың соргылт күзләре капылт кына сычкан тотарга әзерләнгән песәйнеке сымак ялтырап киттеләр.* Я.Хамматов. *Ак хан токымының күкрәгендә ялкын сүнде, арыслан дигәннәре сычкан булып чыкты.* Н.Фәттах

**СЫЮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәнең эченә, өстенә, арасына урнаша алу. *Зәйтүнә белән Тимербулат, Гөлзәйнәп карчык, Әнвәр һәм Лариса бер машинага сыйдылар, такси аларны урман юлыннан, җилтерәтеп, унбиш минутта күл буена илтеп тә куйды.* М.Маликова. *Азны да күп күрә идек Без бәләкәй чакларда. «Күп» җиләкләр сыя иде Сыңар чыныякларга...* Н.Измайлова

2) Тишек, аралык һ.б.ш. аркылы кысылмыйча, тоткарланмыйча үтә алу. *Стеналарда кул сыярлык ярыклар барлыкка килгән, обойлар кубып төшкән.* Кызыл таң

3) Эче, куышы җитәрлек зур булып, берәр нәрсәгә кидерерлек булу. *Ләлә, җаным! Мә, башмакларымны киеп кара, аягыңа сыямы?* Д.Аппакова

4) Берәр кеше янында сыену урыны табу яки берәр җирдә урнаша алу. *Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган, һәр ничек мин бу семьяга сыймаганмын.* Г.Тукай. *Хәзер ул туганыңа да сыя алмыйсың, ике бала белән түгел, ялгызың да...* Р.Даутов

5) Әдәп нормаларына, канунга ярашу, каршы килмәү. *Хәер, чын каләм әһелләренең гомере арифметик саннар кысасына сыя алмый.* Ш.Камал. *Бер дә килешми бу эшең. Законга сыя торган эш түгел. Син үзеңә-үзең дошман шикелле кылангансың...* С.Рафиков

6) Берәр хис, кичереш, сер һ.б.ш. күңелдә, йөрәктә генә калу, тышка бәреп чыкмау, фаш булмау. *Нәни принцның шатлыгы эченә сыймый.* Р.Вәлиев. *Авылга кайтып, сер сыйган дуслары белән кичләр, төннәр буе сөйләшеп утыра.* Р.Батулла

**Сыеп бетү** Тулысынча сыю. *Хәзерге төп байлыгым очлы борынлы, брезент сүрүле шушы тар көймәгә сыеп беткән икән ләбаса!* Г.Фәйзуллин

**Сыя башлау** Сыю мөмкинлеге барлыкка килү. *Тора-бара халык мәйданга сыймый башлады.* Н.Сәфәрев

**Сыя язу** Авырлык белән сыю; тулысынча сыеп бетмәү

**СЫЯК** *и. диал.* Йөз, бит, төскыяфәт, тышкы күренеш

**СЫЯ́У** *и.* Чабата үргәндә кулланыла торган, берникадәр кәкре яссы без рәвешендәге корал; шөшле

**СЭР** *и. ингл.* Инглизчә сөйләшә торган илләрдә: ир кешегә ихтирам итеп мөрәҗәгать итү яки атау. *[Кент:] Бу сезнең улыгызмы, милорд? [Глостер:] Әйе, сэр, минем җимеш.* У.Шекспир. *[Равил:] Мин барыгызны да беләм. Менә бу – Ертык колак. [Ертык колак:] Әүлия икәнсез, сэр!* А.Хәсәнов. *[Официант:] Сэр! Нарядка кулыгызны куйсагыз иде. [Ричард:] Бирегез!* Д.Салихов

**СЮЖЕТ** *и. фр.* Әдәбият, театр, кино һ.б.ш.ларда вакыйгалар, күренешләрнең билгеле эзлеклелеге. *Әсәрләрдәге мавыктыргыч сюжетка корылган вакыйгалар тирән фәлсәфә, нечкә психологизм аша сурәтләнә.* Г.Якупова. *Шигърияттендәге бу үзенчәлек күп төрле сюжет сызыклары тудыруга һәм образны сурәтләүгә этәрде.* Д.Хисамова

**СЮЖЕТЛЫ** *с.* Нигезендә эзлекле һәм бәйләнешле вакыйгалар сурәтләнгән, сюжетка корылган. *Миңа калса, шактый ук төзек сюжетлы, алай гына да түгел, шактый мәгънәле төш, шулай түгелме?* Ж.Дәрзаман. *Шушы нисбәттән соңгы вакытта безнең тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр кузгаткан «Сюжетлы шигырь әйбәтрәкме, әллә фәлсәфи шигырьме?» дигән мәсьәләгә кагылып үтәсе килә.* С.Сөләйманова. *«Сигезенчесе кем?» повесте – психологик сюжетлы, үкенечле язмыш әсәре.* Ф.Хатипов

**СЮЖЕТЛЫЛЫК** *и.* Сюжетлы булу. *Әсәрдә, сюжетлылыктан бигрәк, сурәт тудыру өстенрәк чыкканлы-*

*гы күренә.* Р.Харис. *Җырда сүзләр зур урын тота. Алар табигать, тормыш күренешләренә, кеше кичерешләренә аңлатма биреп, фикерләрне ачыкландыралар, тасвир көчен арттыралар, сюжетлылык тудыралар.* Җ.Фәйзи

**СЮЙТА** *и. фр. муз.* Эчтәлекләре һәм төзелешләре белән төрле характерда булган берничә мөстәкыйль бүлекле инструменталь я симфоник әсәр. --- *Мансур Мозаффаровның зур күләмле музыкаль әсәр булган сюитасы һәм увертюрасы, Җәүдәт Фәйзинең «Комсомол җыры» XV еллыкның уңышлары булып яңгырый.* Х.Туфан. *Соңгы елларда К.Сатиевның баян өчен махсус язылган «Агыйдел буенда» дип исемләнгән дүрт кисәктән торган сюитасы пәйда булды.* М.Макаров

**СЮРПРИЗ** *и. фр.* 1) Искәрмәстән, уйламаганда бирелә торган бүләк һ.б.ш. нәрсә. *Кичен прокуратурада Долин һәм Латыйпов белән очрашып, аларның трофейларын күргәч, Сөләйманов чиксез гаҗәпләнде: – Менә ичмасам сюрприз! Чынлап та болар... Үзегез дә инде... – диде ул, соклануын яшерә алмыйча.* Ф.Галиев

2) Көтелмәгән эш-хәл. – *Ну егетләр, мин сезгә сюрприз ясадым, – диде Сәгыйть, канәгатьләнеп кулларын уауа.* Р.Хафизова. *[Әдиләнең] Район шаулатырлык сюрприз ясарга исәбе.* М.Хәбибуллин

**СЮРРЕАЛИЗМ** *и. фр. сәнг.* 1920 нче елларда Франциядә барлыкка килгән, чын образларны хыялый һәм кеше ышанмаслык, парадоксаль формаларда куллануга нигезләнгән әдәбият һәм сәнгать агымы. *Модернизм – киң күренеш. Ул экспрессионизм, кубизм, футуризм, конструктивизм, имажинизм, сюрреализм, абстракционизм, поп-арт, абсурд театры һ.б. агымнарны колачлый.* К.Гыйззәтов. *Язучы үзе яшәгән җәмгыятьне я сюрреализм, я критик реализм, я романтизм, я сюрреализм методына таянып яктырткан.* Ф.Яруллин

**СЮРРЕАЛИСТ** *и.* Сюрреализм тарафдары

**СЮРРЕАЛИ́СТИК** *с.* Сюрреализм агымына караган, шуңа бәйле булган. *Диварда сәгать һәм сюрреалистик портретлар эленеп тора.* С.Гаффарова. *Кешеләрнең Үлем белән очрашкач булган үзара мөнәсәбәтләрендә реалистик стиль сакланса да, ситуация һәм вакыйгаларны оештыруда тулаем сюрреалистик тасвирлау элементлары, абсурд театры алымнары да бар.* А.Әхмәдуллин

**СЮРТУК** *и. фр.* Ике якка да төймәләнә торган, билле, озын чабулы ирләр өс киеме. *Кыяфәте белән могтәбәр булып тоелган, үзе һәрчак ыспай кара сюртук киеп йөргән, ике кулының да бармакларына алтын йөзекләр таккан.* Р.Мостафин

**СЮРТУКЛЫ** *с.* Өстенә сюртук кигән. *Полиция чиновнигы әле яңа гына өйгә кергән яшел күзле, сюртуклы бер кешегә текәлде.* А.Расих

# Т

**ТА** I *кис. к.* **да** I

**ТА** II *бәйл. фар. иск. кит.* 1) Бәйле сүзнең алдыннан килеп, «кадәр, чаклы, тикле» мәгънәсендә кулланыла. *Моны инде ул та кыямәт онытачак түгел.* Ә.Еники

2) Бәйле сүзнең алдыннан килеп, «чакта, вакытта» мәгънәсендә кулланыла. *Та терек син, пир хезмәтен кылгыл мөдам.* Ә.Ясәви

3) *-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* кушымчаларына беткән сүзләр алдыннан килеп, «башлап, тотынып» мәгънәсендә кулланыла. *Талигымдыр та әзәлдән – һәр эшем бозгын төшәр.* Дәрдемәнд

**ТАБА** I *и. фар.* 1) Азыкны кыздырып әзерләү өчен кулланыла торган кырлары өскә бөгелгән түгәрәк савыт. *Озакламый анда таба чыжлаганы ишетелә башлады.* Ф.Яруллин. *Таба уттай кызган – Бармагыңны кызган.* Ж.Тәрҗеманов

2) Шунда кыздырылган, шуның белән исәпләнгән ризык күләме. *Биш таба коймак ашап бетерү*

◊ **Таба битле** *к.* **табак битле**. *Машинаны көзге бурсык кебек симез гәүдәле, таба битле сержант туктата.* Т.Галиуллин. **Табадан төшү** 1) Камыр ашларының әле генә пешеп чыгуы турында. *Хәзер генә табадан төшкән коймакларны кунаклар алдына таратып, чәй ясый башладылар.* Г.Ибраһимов; 2) Гомумән берәр нәрсәнең яңа гына әзер булуы, дөньяга чыгуы, таралуы һ.б.ш. турында. *«Урам» (Габделфәт Сафин), «Агыйдел кызы» (Илмир Газизуллин) кебек җырларның һәркайсы табадан төшү белән хитка әверелде.* Кәеф ничек? **Табада кыздырган (куырган) кебек** Кояш бик нык кыздыру турында. *Төрекмән кояшы җир йөзендәге мәхлукатны табада куырган кебек куырачагы иртәдән үк мәгълүм иде.* Ш.Мөхәммәдев. **Таба исе чыгару** Бәйрәмнәрдә, гадәттә гает көнне, бәйрәм сые буларак камыр ризыклары пешерү йоласы турында. *[Әкълимә:] Борыны ис сизеп йөри, димә, кергәч сизә башладым, таба исе чыгаргансың, Гөләндәм.* Ф.Хөсни

**ТАБА** II *бәйл.* 1) Субъект башкарган эш-хәрәкәтнең объектка юнәлгәнлеген күрсәтә, юнәлеш мәгънәсе белдерә торган бәйләү чарасы ролен үти; табан. --- *отряд җирдән калыкты һәм, эре-эре атлап, имән төбенә таба килә башлады.* Г.Гобәй. *Баш врач, ишекне ачкан хәлдә, егеткә таба борылды.* Л.Ихсанова. *Коры утын, гөмбәзгә сыймыйча, аңа таба ыргылды…* А.Гыйләҗев

2) Фәзадагы торышның юнәлешен ачыклап килә; табан. *Сәхип куркуыннан түбән таба карап тора иде.* Ш.Камал. *Җырлар миңа яшәү юлын күрсәттеләр, Артка таба чигенмәскә өйрәттеләр.* Ә.Ерикәй

3) Вакыт барышының билгеле чиккә якынаюына күрсәтә. *Кичкә таба җил кузгалды.* Г.Минский. *Өйләгә таба авылның кыйбла як башындагы зур чирәмгә Сабан туе өчен мәйдан ясыйлар.* Г.Ибраһимов

**ТАБА АШЫ** *и.* Табада пешерелә торган камыр ризыклары (коймак, бәлеш, кабартма, өчпочмак һ.б.ш.). *– Мин дә таба ашы пешерергә камыр куя торам, – дип калды.* Б.Ислам

**ТАБАГАТЬ** *и. гар. иск.* Китап басу эше, полиграфия. *Язу, хәреф һәм табагать һөнәренең дөньяга чыгуы гыйлемкәшфият вә һөнәрнең җәелүенә сәбәп булды.* Шура

**ТАБАГАЧ** *и.* Табаны эләктереп мичкә кую-алу өчен бер башында тимер каптыргычы булган таяк. --- *әни кеше табаны күмер өстеннән табагач белән тартып та ала, --- теге хикмәтле ипине дүрткә аерып, балаларга тоттырып та куя.* М.Мәһдиев. *Җиңгинең кулыннан табагач төшеп китте.* Ә.Айдар

◊ **Табагач муен** Тиргәү, орышу сүзе. *[Салих:] Ах, табагач муен, табагач муен! Соң бит, юк-бар сүз сөйләп, укыган намазларыңны әрәм итәсең.* Һ.Такташ. **Табагачы озын** 1) Озын куллы кеше турында; 2) Аш-су әзерләгәндә, ярдәмчеләре, гадәттә кул арасына керерлек балалары, таянычы булган хуҗабикә турында

**ТАБАГАЧЛЫ** *с.* 1) Табагачы булган. *Табагачлы таба*

2) Саплы, тоткалы. *Мичнең икенче бер кырыендагы култыкланып тора торган бер җиргә, кечерәк бүкән башына утырткан табагачлы лампа белән, ватылгач, яңадан җыеп замазка белән ябыштырылган чынаяклар, чәйнекләр куелган булалар иде.* М.Гали

**ТАБА́ ИПИЕ** *и. диал.* Әче камырдан табага салып мичтә пешерелә торган, коймактан калынрак һәм зуррак камыр азыгы; табикмәк. *Авылда --- чөгендер пәрәмәче, таба ипие пешерәләр.* М.Мәһдиев

**ТАБАК** I *и. гар.* 1) Хуҗалыкта кулланыла, төрле зурлыкта һәм тирәнлектә була торган түгәрәк җәенке савытларның гомуми атамасы. *Өйдә, табак тутырып, бәрәңге пешергәннәр.* Г.Ибраһимов. *Илсөяр, котомкасын чишеп, ялкында тозлап кыздырылган бер балык алды да аралыктагы песи табагына китереп салды.* Г.Гобәй

2) Төрле үлчәү, прибор, аппарат һ.б.ш.да зур тәлинкә төсле савыт. *Аның [багана] янында зур табаклары асылган үлчәү.* А.Әхмәт

3) Формасы белән шундый савытка охшаган, шуны хәтерләткән әйберләр турында. *Төнге кошлар Алтын Ай табагын Кисеп очты, тыгыз төркемдә.* С.Гәрәева

4) Шул савыт тулырлык яки шундый савытка сыешлы әйбернең микъдар күләме. *Таза инде менә: бер ашаганда дүрт табак ботканы, бер кирпеч ипине ишеп кенә куя.* М.Мәһдиев

◊ **Табак битле** Киң яссы йөзле кешегә карата. *Мәхәббәт дигәндә, кәкре*

*аяклы, ялбыр колаклы, табак битле Шиһапның гыйшык тотып йөрүләрен күз алдына китерүе кыен хәзер.* М.Кәрим. *Мөселманнар арасында табак битле, юантык гәүдәле симез кыз-хатыннар күркәм санала.* М.Әмирханов. **Табак йөзле** *к.* **табак битле**. **Табак өеме** Табакка өеп тутырылган, табак тулы. *Шулпа артыннан каз бәлеше, бәлеш артыннан табак өеме ит килде.* Ә.Еники. **Табак түбәсе** Ашамлыкның иң тәмле кисәге, иң майлы урыны турында. *[Гөбәнәй] ат итенең симезен генә табак түбәсеннән ашап, корсагын юри юанайта.* Ш.Маннур

**ТАБАК** II *и. гар.* 1) Кәгазь, калай, пыяла кебек яссы нәрсәләрнең билгеле зурлыктагы һәм формадагы кисәге. *Әнә Шәммәтнең урта бер җиренә диярлек металл табаклардан иләмсез зур һәм имәнгеч бер бина корып куйдылар.* Р.Миңнуллин

2) *махс.* Басма текстны үлчәү берәмлеге. *Бер әдип бер ел эчендә 5–10 табак чамасында нәрсә биреп, моның өчен 1000 сум каләм хакы алса, шөбһәсез, аның белән ул бу әсәрләргә киткән энергиянең бик аз өлешен кире кайтарып ала.* Ф.Бурнаш. *--- повесть, табак ярымга кыскартылып, татарча да дөнья күрү бәхетенә иреште.* Ә.Баян

**ТАБАКЛАП** I *рәв.* 1) Билгеле табак (I) чамасында. *Атланмаем капламалап, сарымаем тәпәнләп, туңмайларым табаклап ята.* Т.Гыйззәт

2) Табаклар (I) санынча; табак-табак итеп; табагы-табагы белән

**ТАБАКЛАП** II *рәв.* 1) Билгеле табак (II) чамасында. *Сайлап алырга иркен булсын диптер инде, шигырьләрне, калын папкага салып, күп итеп җибәргән, гомум күләме унбиш табаклап бардыр.* Н.Нәҗми

2) Табаклар (II) санынча; табак-табак итеп; табагы белән

**ТАБАКЛА́У** *ф.* Табакларга (II) аеру; табак үлчәме белән бүлү

**Табаклап бетерү** Табакларга аеру, бүлүне тәмамлау

**Табаклап кую** Алдан ук табаклау

**Табаклап тору** Озаклап яки әледән-әле табаклау; әле, хәзерге вакытта табаклау

**ТАБАКЛЫ** I *с.* 1) Табакка (I) тутырылган. *Мин [Закир], ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атылып, йортка чаптым.* Г.Ибраһимов

2) Табакка охшаган өлеше булган, дисклы. *Менә шушы өстәлгә ике табаклы бизмән китереп астым да бер табагына Галимҗан Ибраһимовның башын китереп салдым. Икенче табагына мәдрәсәдәге шәкертләрнең башларын өя башладым.* С.Кудаш

**ТАБАКЛЫ** II *с.* 1) Табак (II) формасындагы. *Гади йөк машинасында утыручыларны кеше күзеннән яшерү өчен, чекистлар бик ансат юл уйлап табалар: ян-як бортларга, алга һәм артка табаклы фанер кадаклап куялар.* А.Тимергалин. *Биредә югары сыйфатлы табаклы калай җитештереләчәк.* Т.Сабирҗанов

2) Билгеле табак (II) күләмендә булган. *Әхәт ярты табаклы кәгазьне шатырдатып ертты.* А.Алиш. *Хәзергедәй күз алдымда: озын өстәлгә җәелгән зур табаклы кәгазь.* Г.Кудашев

3) Кәрәз төпләренең эзе төшерелгән бик юка һәм дөрес турыпочмаклык формасындагы балавыз каты булган (бал тур.). *Габденнасыйр, табаклы балдан кул кисәге кадәр кәрәзле балны кисеп, Шөгаепнең кулына тоттырды.* М.Гали

4) Тукылмыйча, гадәттә берәр синтетик чималдан ясалган тукымасыман материал

**ТАБАКЛЫК** I *с.* Билгеле табак (I) күләмендәге; билгеле табак санына сыярлык яки җитәрлек. *Ашады, икенче табакны китердек, ашады: вәлхасыйль, ун табаклык ашны тәмам ашады.* К.Насыйри

**ТАБАКЛЫК** II *с.* Билгеле табак (II) күләмендәге; билгеле сандагы табакка сыярлык яки җитәрлек. *Пицундага барып, «Ф. Әмирхан» дигән ике табаклык очерк язарга тиешмен.* М.Мәһдиев. *Әгәр сез, ун табаклык романыгызны бастырып чыгарырга теләп, нинди дә булса типографиягә барсагыз, мең данәсе өчен якынча йөз мең сум акча түләргә тиеш булачаксыз.* М.Кәбиров

**ТАБАК-САВЫТ** *җый. и.* Табында кулланылган һәм җыештырып алына, юыла торган савыт-саба. *Сөйләшә-сөйләшә, табак-савыт юып ятканда, ашханәгә директорлары Серафима Николаевна белән аның тәрбия буенча урынбасары Алевтина Александровна килеп керде.* Ә.Сафиуллин. *Өйдә тәртипсезлек: баланың киеме алыштырылмаган, идән уенчык белән тулган, табак-савыт юылмаган, ашарга әзер түгел, суыткычта берни дә калмаган.* Хәбибә

◊ **Табак-савыт шалтырау** Гаиләдә төрле хәл булу, шау-шу чыгу турында. *Гаиләдә табак-савыт шалтырамый тормас.* Ә.Рәшит. *Хуҗа белән хуҗабикә арасында тынычлык урнаштырырга кирәк, табак-савыт шалтырый башларга чамалый кебек, дигән уй узды башымнан.* Г.Тавлин

**ТАБА́К-ТАБАК** I *с.* **1.** 1) Табакларга салынган; табаклап исәпләнгән. *Өстәл тулы табак-табак алма, йөзем кебек җимешләр.* М.Хәбибуллин. *Табак-табак пәрәмәч пешереп куя идем.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Күпсанлы табаклар рәвешендәге. *Юл читендәге чокырлы урыннарда табак-табак сулар ятып калды.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Табаклап, табакларга бүлеп. *Табак-табак бүлү*

2) Күп итеп (яки киресенчә – азазлап), табаклары белән. *Табак-табак өләшү*

**ТАБА́К-ТАБАК** II *с.* **1.** Табаклар II рәвешендәге. *Безнең кулдагы --- табак-табак калын кәгазьләрне күргәч, бу егетнең йоклап яткан җеннәре кузгалды.* Ф.Хөсни

**2.** *рәв. мәгъ.* Табаклап (II), күп итеп. *--- Ельцинга табак-табак хатлар язды ---.* Ф.Бәйрәмова

**ТАБАКТАШ** *и.* Табындаш, гомумән, кем белән дә булса аралашып, кунакка йөрешеп яшәгән кеше. *Баһман белән без --- табакташ булсак та, яшьтәш түгел идек.* А.Таһиров

**ТАБА́ КҮМӘЧЕ** *и. диал. к.* **таба ипие**. *Габдулла өйдән биш данә каты пешкән күкәй, зур гына таба күмәче алып килгән иде.* Ә.Фәйзи

**ТАБАКЧЫ** *и.* Зур мәҗлестә аш өләшүче; аш-су китереп торучы; аякчы

**ТАБАЛА́У** *ф. сөйл.* Нинди дә булса ялгыш, җитешсезлек, кимчелек һ.б.ш.

өчен кирәгеннән артык битәрләү, әрләү, гаепләү. *Гарьләнеп, үзен үзе табалап, ни эшләргә белми ул.* Х.Камалов. *Моңарчы яшереп килдем, Күктимер: миңа көн күрсәтми синең анаң, көн саен табалый, көн саен битәрли.* Р.Батулла

**Табалап алу** Бераз табалау

**Табалап бетерү** Бик нык табалау

**Табалап тору** Даими рәвештә яки әледән-әле табалау; әле, хәзерге вакытта табалау. – *Ярамый болай, ташларга кирәк бу эшне! – дип, үзен әледән-әле табалап тора иде.* В.Нуруллин. *Ул үзенчә юрады: Айгөлнең ире көнчел икән, табалап кына тора икән, дип ишеткәне бар.* Ә.Моталлапов

**Табалый башлау** Табаларга керешү. *Ә ире кайта да Зәмзәмиясен табалый башлый, нигә моңа кадәр миңа бу турыда әйтмәдең, ди.* Р.Вәлиев

**ТАБАЛАШУ** *ф. урт. юн. к.* **табалау**

**Табалашып алу** Бераз табалашу

**Табалашып китү** Кинәт табалаша башлау

**Табалашып кую** Аз гына табалашу

**Табалашып тору** Әле хәзер табалашу; даими яки әледән-әле табалашу

**ТАБАН** I *и.* 1) Аякның басып йөри торган аскы ягы. *Икенче минутта Ваһапов табаны юешләнүен тойды, яраланганлыгын аңлады.* Х.Камалов. *Фермага кичке эшкә барганда ук, аяк табаннарым кыза, беләкләрем өзелеп төшәрдәй булып сызлый.* Р.Корбанова

2) Аяк табанының уртача озынлыгына тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Хәзер генә ул элек тә сәгать тагып йөргәнбез кебек тоела. Җир сөргәндә төш җиткәнне, ничә чабата табаны икәнен үлчәп, күләгәдән белә идек.* Ш.Галиев

3) *диал.* Аякның үкчә өлеше

4) Кулның аркасына каршы эчке ягы, уч ягы. *Йөзекнең кашын уч табанына таба киде.* К.Насыйри

5) Аяк киеменең төбе, олтаны. *--- Сабирҗанов --- папиросын итек табанына басып сүндерде дә урыныннан торды.* Ә.Еники. *---[тимерчыбыкка] абынып, мин үзем дә күп азапландым. Чалбарымны ертып, ботинка табаннарымны тишеп бетердем.* А.Хәсәнов. *Карда, бозда шуа-шуа, итекләремнең табаны бик тиз юкара иде.* Р.Низамиев

6) *диал.* Аяк киеменең үкчәсе. *Француз туфлиенең очлы табанында зың итеп әйләнеп, борылып китеп кенә барасы иде дә, хатын-кызлык табигате җиңде.* Т.Галиуллин

7) *окказ.* Аякның аскы өлешен генә каплый торган җәйге ачык аяк киеме. *Саргылт аксыл, кырыйлары чигелгән 4–5 метрлы тукыманы җилкәсеннән, аяк арасыннан уздырып, гәүдәсен чорнаган да ялан аякка табаннар эләктергән [гид].* М.Мәһдиев

8) Чананың җирдән шуып бара торган, алгы ягы өскә таба бөгелеп күтәрелеп торган тар агач яки тимер буйдан гыйбарәт аскы парлы детале. *Аннары сәләмә атка җигелгән, үрәчә баулары өзелеп, табаннары ашалып беткән сәләмә чанасына өч кыз төяп, Равил юлга чыга.* В.Нуруллин. *Ә менә элмә агачы дуга бөгәргә, тәгәрмәч тугымына, чана табанына әйбәт!* Г.Гыйльманов

9) Трактор һ.б.ш. машина-механизмнарның җир өстеннән бара торган җәенке өлешләре, чылбыры. *Ул, үзенә яңадан тормыш дәрте кайтканын тойган хәлдә, трактор табаннары бастырып киткән эздән чыкмаска тырышып, комбайн каршысына йөгерде.* Н.Фәттах. *Танкның җыерчыклы табаннары күпме генә таптаса да, Кырмыска качып калырлык ярык табылып тора икән.* Г.Гыйльманов

10) Гомумән берәр зур әйбернең аскы өлеше

11) *күч.* Берәүнең аяк асты, каршындагы җир. *Юлдаш булсаң дус күренгән монафикъка, ташлап китәр дошманның табанына.* Акмулла

◊ **Табан астында булу** Кемдер тарафыннан изелгән, буйсындырылган булу. --- *җыелышта Батулла, трибунага чыгып: «Рус табаны астында булуга караганда, төрек табаны астында булу артыграк», – дигән сүз әйтте.* Н.Фәттах. **Табан астында җир (ут) яну** Берәр төрле куркыныч янау. *Ә үзеңнең табаннарың астында ут яна башлаганын тоймыйсың син.* В.Имамов. **Табан астында олтырак булу** Бик түбәнчелек белән ялыну, гафу үтенүне белдерә. *Моннан болай гайбәтеңне чәйнәмәм, дип әйт! Табан астыңда олтырак булыйм, дип әйт!* Г.Бәширов. **Табан астында туфрак булу** *к.* **табан астыңда олтырак булу**. *Табаныгыз астында туфрак булырга да риза ла без!* Н.Сәйяр. **Табанга ут капкан кебек (сыман)** Бик тиз, нык ашыгып. *Офыкка таба йөгерде, Табанга ут капкан сыман. – Таң капкасын ачучылар, Мин чыгам ---.* Л.Зөлкарнәй. *Аннан... атаңның вакыты да юк шикелле. Табан астына ут капкан кебек йөри...* Т.Гарипова. **Табан кызу** Йөгерергә, йөрергә күнегә башлау, ияләшү. *Табаны кызганчы тай узар, Табаны кызса – ат узар.* Әйтем. *Хәер, табаннары кызгач, ул юл салкынын да сизми башлады.* Ф.Яруллин. **Табан майлау** Каян да булса качарга әзерләнү, качу. *Еллаган, айлаган да табанын майлаган.* Әйтем. *Без, кеше-кара күз ачканчы, чокыр буйлап сыпырдык. Табаннарны шәм белән майларга кирәк, атаман, алар хәзер монда кузгалачак.* Ш.Шәйдуллин. **Табан терәп** *к.* **аяк терәп**. **Табан терәү** Тормышта нинди дә булса ышанычлы терәк табу. *Әле тормышта табан терәрлек мөмкинлекләре сакланып кала алган Хәйрулла кебекләр, иң яхшы дигәндә, үсеп килә торган улларына өмет баглаганнар.* Х.Госман. *Табан терәп кайда басып торыйк, ди, без ул чакта?* Ф.Садриев. **Табан шомарту** 1) Бернинди эшсез, максатсыз бер тирәдә таптану, йөренү; 2) Бию. *[Сәйфулла:] Әйдәгез, егетләр, [аулак өйгә] кертәләр. Бер табаннарны шомартып чыгыйк [эчтән бию көе ишетелә].* Ф.Бурнаш. **Табанына басып** Артыннан ук, кемнән дә булса бер адым да калышмыйча; алдагыларны ашыктырып. *Әмма күп булса биш чакрымнардан без аларның барысын куып җитәбез, табаннарына басып бара башлыйбыз.* А.Хәсәнов. *Аның [Ольганың] табанына басып килүче норвегияле Солемдаль Синов өч тапкыр сынатты һәм 450 метр штрафка «лаек» булды.* Кызыл таң. **Табаныннан очкын чыгу** Бик матур, оста итеп бию; гомумән җиңел, җитез хәрәкәтләнү. *Бер-берсенә такмак әйтеп бии башлыйлар. Табаннарыннан очкын чыга. Бөтен галәм аларга кушылып бии.* Т.Галиуллин.

**Табанын үбү** 1) Берәү өчен теләсә нинди гамәлгә әзер булу, бик бирелгән, тугры булу. *Минә шушы Миләүшә Бәхтиярова бер дигән егет Толик Бакалинга нигәдер игътибар итми шул, гәрчә Толик аның аяк табаныннан үбәргә әзер булса да.* А.Хәсәнов. *Мин синең табаныңны да үбәргә әзер, куш кына.* Р.Камал; 2) *к.* **табан ялау**. **Табаныңа төшәрлек** Нык тәэсир итә торган, үтемле, гайрәтле. *Исән-саулык өчен күтәрдек. Кая инде ул безнең «экстра» Табаныңа төшеп җитәрлек!* Г.Афзал. *– Алгач-алгач, [аракының] агын ал инде, балдыз, – мәйтәм. – Табанга ук төшәрлек булсын.* Ф.Баттал. **Табаны пешкән мәче (песи) кебек (төсле)** Кабаланып, үрсәләнеп йөрү турында. *Һи-и, ди, каян табарга икән, дип, табаны пешкән мәче кебек пырх-пырх килеп борсалана, ди.* Х.Камалов. *Эшнең кая таба барганын аңлагач, әле син табаны пешкән мәче кебек бөтерелерсең, тик ул чакта соң булыр, дип янады ул Шаһзамановка.* Ф.Садриев. **Табаны төшү** Күп йөрүдән тәмам ару, аяктан калу. *Балаларының артыннан йөрийөри ата-аналарының табаннары төшә.* Ф.Яруллин. **Табан ялау** Кемгә дә булса артык түбәнчелек белән ярарга тырышу, бик түбәнсенеп ялагайлану. *Юкса егетләрнең иң асыллары аның табанын яларга тормас иде.* Ф.Яруллин. *Без хәзер берәүгә дә ясак түләмибез, берәүгә дә баш иеп бармыйбыз, берәүнең дә табанын яламыйбыз.* М.Әмирханов. **Табан ялтырату** Бик тиз, ашык-пошык качып китү. *Хәзер бу тирәдән табанны ялтыратсаң да ярый торгандыр.* Н.Әхмәдиев. *Ул абзыкай әллә кайчан табан ялтыраткандыр инде.* А.Тимергалин

**ТАБАН** II *и. зоол. к.* **табанбалык**. *Ярты сәгать үтми, без бер-бер артлы эре табан балыкларын суырып чыгара да башлыйбыз.* И.Гыйләҗев. *--- чуртан булмаса, табаннар йоклап әрәм булыр иде.* Г.Хөсәенов

**ТАБАН** III *бәйл. к.* **таба** II. *Картлыгыңа табан атлаган саен, ярасы тирәнәя генә.* Н.Гыйматдинова. *Айдар диңгез күренгән якка табан бар көченә чабарга кереште.* И.Диндаров

**ТАБА́НБАЛЫК** *и. зоол.* Карпсыманнар семьялыгыннан промысел һәм үрчетү объекты булган кызгылт төстәге җәенке гәүдәле балык; кәрәкә. *Яңа гына күлдән чыккан табанбалык ухасын --- ашамаган кешеләр бу ашларның ләззәтен барыбер тоя алмаячаклар.* Ш.Маннур

**ТАБА́Н БИЛЕ** *и.* Табан астының урта бер җирендә уемлы өлеше. *Кешенең табан биле беленер-беленмәс кенә булса, ул киң күңелле кеше була.* Н.Исәнбәт

**ТАБАНГЫ** *бәйл. диал.* «Билгеле юнәлештә», «билгеле вакытка якын» мәгънәсен белдерә. *Контора дигәннәре лабаздан бер йөз адымнар чамасы читтә тәбәнәк кенә бер өйчек булып, аның диңгезгә табангы ягында --- тагы бер казарма бар иде.* Ш.Камал

**ТАБАНЛА́У** *ф.* 1) Табан I (*8 мәгъ.*) кую. *Арбалар тимерлим, чаналар табанлыйм, сабаннар, йозаклар төзәтәм, атлар дагалыйм, кыскасы, авыл тимерчесе нәрсә эшли – барысын да эшлим.* А.Шамов

2) Табан I (*2 мәгъ.*) берәмлеге белән үлчәү

3) *диал. күч.* Әкрен генә атлап китеп бару. *Кая болай табанлыйсың?*

4) *диал. күч.* Качу, качып китү, табан ялтырату

**Табанлап алу** Тиз арада табанлау

**Табанлап бетерү** Тулысынча табанлау; барысын да табанлау

**Табанлап тору** Вакыт-вакыт яки берөзлексез табанлау; әле, хәзерге вакытта табанлау

**Табанлый башлау** Табанларга керешү

**ТАБАНЛЫ** I *с.* Билгеле сыйфаттагы табаны булган. *Кыш көннәрендә аны калын ак кар каплап китә, аның өстеннән кар-бураннар себереп, бозлы җилләр исә, салам салган туң табанлы чаналар йөгертеп уза ---.* Н.Фәттах. *Мин, иртән торып, йомшак табанлы песи баласы шикелле, аяк очларына басып, кухняга чыгам.* Э.Яһудин. *Аягында биек табанлы шәп туфлие зифа буен тагын да сылурак итә.* Н.Каштанов

**ТАБАНЛЫ** II *с.* Үзендә табан балыгы күп булган. *Табанлы буа*

**ТАБАНЛЫК** *и.* **1.** Табан I (*5, 8 мәгъ.*) ясау өчен билгеләнгән, шуңа яраклы материал. *Табанлык сатып алу*

**2.** *с. мәгъ.* Табан ясарга яраклы, шуңа җитәрлек. *Табанлык киез. Табанлык тимер*

**ТАБАНСЫЗ** *с.* **1.** Табаны булмаган. *Бичараларның өстендә бер кат җилән, аякларында табансыз читек, шул көенчә чатнама суыкта мәет күтәреп баралар.* Т.Гыйззәт

**2.** *рәв.мәгъ.* Табан булмаган көе, табаны булмый торып, табаннан башка. *Эзли-эзли табансыз калдылар.* А.Гыйләҗев

**ТАБА́Н-ТАБАН** *рәв. сир.* Кемнең дә булса эзенә басып, артыннан бер адым да калмыйча. *[Наширны] Хезмәтчеләр куа эздән табан-табан.* Г.Тукай

**ТАБАНТЫН** *бәйл. иск.* Ягыннан, юнәлешеннән. *Урман табантын килү*

**ТАБАНЧА** I *и.* 1) Табанга I (*5 мәгъ.*) беркетелә торган өстәмә катлау. *Итекче Гыйлаҗи: «Камәретдин дус, минә нәрсә, иске чирбикләреңне миңа китер, минә дигән көннән табанча салып бирермен», – диде.* К.Тинчурин

2) Чана табанына беркетелә торган калай тасма. *Чанага табанча кадаклау*

3) Трактор, танк һ.б.ш.ларның тимер чылбыры; гусеница. *[Гәрәй:] Кулым танк табанчасына эләгеп, үземне яткан җирем-балчыгым белән яньчеп, күтәреп алып бәрде.* Н.Исәнбәт

4) *окказ.* Агачтан юнып эшләнгән, аяк киеменең табанына беркетеп, такыр карда, бозда шуа торган җайланма. *Ул арада табанча шуучы кыз балалар да килеп җитте.* Р.Батулла

**ТАБАНЧА** II *и. иск.* Кыска көпшәле утлы корал, пистолет. *Эш беткәч, биш җөрге ат, берданә арка чана, көмеш көпчәкле арба, алтын төпсә, һәр хатыныңа ас тиресеннән тун, толып, ике табанча, бер мичкә дары синеке булыр...* Р.Батулла. *Кәбир урыс кулыннан табанчаны бәреп төшерде.* Яшел Үзән

**ТАБАНЧАЛЫ** *и.* Табанчасы I (*1 мәгъ.*) булган. *Табанчалы итекләр киертеп йөртмәде ул аларны.* Яшел Үзән

**ТАБА́ РИЗЫГЫ** *и. к.* **таба ашы**. *Бу исне аның сугыш башланганнан бирле*

*сизгәне юк иде. Нәрсәдер, таба ризыгы.* М.Мәһдиев

**ТАБА-ТАПЧЫК** *и.* Берәүләр качып, берәү аларны эзләүдән гыйбарәт балалар уены; сукыр тәкә уены

**ТАБАТЫН** *бәйл. иск. к.* **табантын**. *--- янган күлдән табатын түбән очның Галәви Хөсниләре килеп чыктылар ---.* М.Гали

**ТАБАЧА** *и.* 1) Кечкенә таба

2) *диал.* Чынаяк асты, чынаяк тәлинкәсе. *Табачага салып чәй эчү*

**ТАБӘКА** *и. гар.* Катлау, сыйныф; даирә. *Болар – адәмгә караганда түбән табәкада тора торган нәрсәләр.* Ф.Әмирхан. *Оксфорд вә Кембридж дарелфөнүннәре – Англиянең бай табәкасына махсус мөәссәсәләрдер.* С.Максуди. *Ул заманда үзен гавамнан югарырак табәкада санаган һәрбер татар, кулына каләм алса, ихтыярсыз сарт булып китә иде.* Җ.Вәлиди

**ТА́БГАН** *рәв. гар. иск.* 1) Табигый рәвештә, табигатьтән, асылда. *Көз яше --- табган ачыдыр.* Дәрдемәнд

2) Табигате белән, холкы буенча (кеше тур.). *Бу, мин алтатар алачак агай, табган үткен, бәдәнән көчле, үз сүзеннән күчми.* Г.Тукай

**ТАБГЫХАНӘ** *и. гар.-фар. иск. кит.* Типография, матбага, басмаханә. *Биредә, әлбәттә, Казан университеты табгыханәсенең, шулай ук хосусый басмаханәләрнең искиткеч зур эш башкаруын әйтергә кирәк.* Мәдәни җомга

**ТА́БЕЛЬ** *и. нем.* 1) *махс.* Берәр эшгамәл теркәлеп бара торган яки булган әйберләр турындагы мәгълүмат санап кителгән исемлек. *Ата кеше, малаен коткарырга ниятләп, эткә үзенең табель пистолетыннан ата.* Татарстан яшьләре. *Нәтиҗәдә яралы полиция табель коралыннан ут ачарга мәҗбүр була.* Шәһри Казан

2) Мәктәптә укучыларның чирек, яртыеллык, еллык йомгаклары буенча өлгереш исемлеге. *Табельдә бишләр: «Мин кем?» – дип басып торырлар иде.* Д.Аппакова. *Мәктәптә еллык билгеләр куелган табельләр тараталар.* Татарстан яшьләре

3) Эшче һәм хезмәткәрләрнең эшкә килү-китүен билгеләп бару өчен махсус такта, дәфтәр һ.б.ш. *Хәтта табель дәфтәренә иң башлап аны билгеләп куйганын, кыскасы, Нуруллин күңелендә аңа бик тирән җылы хиснең сакланганын белми китте.* А.Шамов

**ТАБЕЛЬ-КАЛЕНДАРЬ** *и. рус* Баганаларына елның көннәре, атна һәм айлары тәртип белән язылган кенәгә. *Фәйзулла мөнәҗҗим, үзе ясаган кораллар белән эш итеп, ай һәм кояш тотылышы, һава хәлләре үзгәреше турында алдан хәбәр бирергә өйрәнә, табель-календарь эшли, сәгатьләр поясын яза.* М.Мәһдиев. *Ул «Горринамә» дип аталган һәм ай, көн исәбен күрсәткән, ягъни табель-календарь кебегрәк булган.* Фән һәм тел

**ТА́БЕЛЬЧЕ** *и.* Табель (*3 мәгъ.*) тотыручы эшче; хезмәткәрләрнең эшкә йөрүен исәпкә алып баручы. *Ул вакыт Нуруллин бу заводта табельче булып эшли иде әле.* А.Шамов. *Фәйзер дә --- аны табельче итеп кабул иттеләр, Миңнегаян алдан околотокта җыештыручы, аннары су кудыру машинисты булды.* Байрак

**ТА́БЕЛЬЩИК** *и. рус к.* **табельче**. *Колхоз хисапчысы, табельщигы, тагын бер активист исемлек буенча аш бүлә.* М.Мәһдиев

**ТАБИБ** *и. гар.* 1) Югары белеме булган медицина белгече; врач. *Надан табиб җаның алыр, надан галим иманың алыр.* Мәкаль. *Югары белемле табиб Фарис Галләм, Наил Хәким --- бик күп авыруларны сихәтләндерүләрен әледәнәле телевизордан күрсәтеп торалар.* Сөембикә

2) Медицина өлкәсендә фәнни тикшеренү белән шөгыльләнгән белгеч, медицина галиме. *Табиблар биологик актив нокталарга электр тогы белән тәэсир итү методын да кулланалар.* Мәгариф

3) *күч.* Гомумән дәвалаучы. *Озак көттермичә килеп җитеп, табигать табиблары «келәй» харап иткән үсемлекләрдән анализлар алдылар.* Шәһри Казан

4) *күч.* Берәр авыр хәлдә күңелне юата, рухи көч бирә торган нәрсә. *Әмма Нәфисәнең иң беренче табибы үзенең бригадир булып эшләве, бодай басуындагы хезмәте булды.* Г.Бәширов. *Вакыт – яхшы табиб. Ярты ел чамасы күрешми торгач, мин аны яңадан сагына башладым.* З.Мәхмүди

**ТАБИБӘ** *и. гар.* Хатын-кыз табиб. *--- килеп китүебезне сорады [Роберт Әхмәтҗанов]. Кызым белән бардык, ул аның табибә икәнен белә иде.* Ватаным Татарстан

**ТАБИБЛЫК** *и.* 1) Табиб вазифасы һәм дәрәҗәсе. *Шуннан бераз элегрәк Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең өч сахабәсен шәһре Болгарга җибәргән һәм анда табиблык хезмәтен дә башкарырга кушкан була.* Ф.Урманчеев

2) Дәвалау эше, медицина. *Ул, дин дәресләре белән беррәттән, гамәли гыйлемнәргә дә өйрәтә торган мәдрәсә ачкан, үзе табиблык белән дә шөгыльләнгән...* М.Кәбиров

**ТАБИБЧЫЛЫК** *и. ялг. к.* **табиблык**

**ТАБИГАТЬ** *и. гар.* 1) Тирә-яктагы органик һәм органик булмаган дөнья, материаль дөнья, галәмдә бар булган нәрсә. *Борынгы галимнәр, табигать серләренә төшенеп ачышлар ясаган саен, ул ачышлардагы гүзәл тәртипне, иплелекне, мәгънәлелекне, зәвыкны тоеп, Ходайга гыйбадәт кылганнар.* Шәһри Казан. *Кар-бураннар, җилдавыллар, көзен корыган яфрак коелу – болар табигать күренешләре.* Өмет

2) Органик дөнья, үсемлек һәм хайваннар дөньясы. *Көн кызуыннан бөтен табигать әлсерәгән.* Г.Гыйльманов. *Бөтен табигать уяна, Каңгылдаша казлар да.* А.Сафин

3) Тудыручы, барлыкка китерүче көч буларак дөнья. *Табигать миңа шундый бер күңел биргән: ямь, нәфасәт алдында бөтен дөньямны онытам.* М.Фәйзи. *Буйны табигать саранланып биргән булса да, кыяфәте генералныкы.* А.Тимергалин. *Табигать-анабызны берөзлексез пычратып, аның зәңгәр күгенә «Оргсинтез», дары заводлары агуларын очыртып, Идел, Казансу кебек елгаларыбызга «шифалы» калдыклар агызып, без үзебез күптән «табигать диверсантлары»на әйләнеп бетмәдек микән инде?* Шәһри Казан

4) Билгеле бер төбәкнең һавасы, җир-суы, үсемлек һәм хайваннар дөньясы һ.б.ш.лардан гыйбарәт таби-

гый шартлары. *Табигате җәннәткә тиң Кырымның.* Р.Мөхәммәдиев. *Биек тау астында урнашкан бәләкәй татар авылының табигате искиткеч матур, чишмәләрендәге суларын эчеп туялмаслык ---.* Д.Гыйсметдин

5) *сөйл.* Шәһәрләрдән читтә булган урыннар: урман, болын һ.б.ш.лар. *Таш өйләр ардырган, машиналар тавышын ишетәсе килмәгән чакларда гаиләбез белән табигатькә чыгабыз.* Р.Рахман. *Көннәр җылы һәм матур торганда, күпләр табигатькә чыгарга, кояш астында ешрак булырга тырыша.* Шәһри Казан

6) Кешенең тумыштан килә торган табигый сыйфатлары, кешенең, кеше организмының ихтыяҗлары, биологик үзенчәлеге. *Күрәсең, адәм баласының табигате шундыйдыр инде: нинди генә эш кылырга тотынса да, башта үзен хаклы саныйдыр, шуңа инанып тотына торгандыр.* В.Нуруллин. *Ләкин хатын-кыз һәм ир-ат кеше табигате буенча бертигез булсалар да (инстинктлар һәм органик хаҗәтләр икесендә дә бар), шулай да төрле җенес вәкилләре буларак аерылалар.* Безнең гәҗит

7) *сөйл.* Характер, холык. *Рәсим табигате белән бераз тәкәбберрәк, әмма Зөлфиянең чаялыгы ул тәкәбберлекне челпәрәмә китерә торды.* Ф.Яруллин

8) Нәрсәнең дә булса асылы, төп үзенчәлеге. *Без сугышның социаль табигатен --- ачкан көрәшченең әче сүзләрен укыйбыз.* М.Җәлил. *Мәрткә китү табигате белән гадәти йокыдан берни белән дә аерылмый.* Безнең гәҗит

◊ **Табигать баласы** Тәрбиясе, холкы, үз-үзен тотышы белән гади, беркатлы, саф күңелле кеше (гадәттә авыл кешесенә карата). *Һәрхәлдә, цивилизация вәкиле булуга караганда күбрәк табигать баласы булып калган Ринатка шулай тоелды.* Җ.Юныс. **Табигать кочагы** Саф һавасы, яшеллеге, суы булган урын. *Шәһәр шау-шуыннан качып, табигать кочагына киткән романтик шәхес диңгездә дә үзенә тынычлык таба алмый.* М.Мәһдиев. *Чыннан да, барыбыз да, табигать кочагына чыгып, саф һава суларга яратабыз.* Р.Низамова. **Табигать эче** *к.* **табигать кочагы**. *Докторлар миңа бернечә айга авылга китеп, табигать эчендә яшәргә киңәш иттеләр.* А.Шамов. *Шул урманда йөреп, табигать эчендә тәгәрәп үстем.* Р.Вәлиев

**ТАБИГА́ТЬ БЕЛЕМЕ** *и.* Табигатьне (*1–2, 4 мәгъ.*) өйрәнә торган фән тармагы. *Безгә мәктәптә табигать белеме керә башлады инде.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТАБИГА́ТЬ ГЫЙЛЕМЕ** *и. к.* **табигать белеме**

**ТАБИГАТЬЛЕ** *с.* Билгеле бер табигатькә ия булган, билгеле табигате белән аерылып торган. *Үги әнисе аз сүзле, тыйнак табигатьле булды.* В.Имамов. *Шушы кадәр матур табигатьле авылны ташлап китү гөнаһ булыр, дим.* Ф.Абдуллин

**ТАБИГАТЬЧЕ** *и.* 1) Табигать белеме белгече. *XIX йөзнең икенче яртысында Казанда күп кенә фәнни җәмгыятьләр барлыкка килә: Казан табиблар җәмгыяте (1868), табигатьчеләр җәмгыяте (1869)*

2) Табигатьне (*1–2, 4 мәгъ.*) өйрәнү белән мавыгучы кеше, натуралист; табигатьне саклау-яклау эшенең актив тарафдары. *Мәктәптә драма-хор, физкультура, атучылар, яшь табигатьчеләр, туристлар түгәрәгенә йөри.* З.Зәйнуллин

**ТАБИГЪ** *хәб. сүз иск.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса тәэсиренә буйсынган. *Җирдәге һәммә алмашынулар – тик аның (кояшның) тәэсиренә генә табигъ.* Г.Ибраһимов

2) Берәүнең хакимлеге астында булу, аның властена бәйле булу. *Госманлы дәүләтенә табигъ булган бу Мәмәт әфәнде кебек шөбһәле затлар Русиядә аз түгелдер.* З.Биһиев. *Барыннан да озаграк көрәшүче таифә башкортлар булган, алар да ике елдан соң Мәскәүгә табигъ булганнар.* Г.Әхмәров

**2.** *с. мәгъ.* Билгеле бер дәүләтнең хакимлегендәге, шуңа бәйле. *Русия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте һәм аңа табигъ мәхәлләләр исеменнән Корбан бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итәм.* Кызыл таң

**3.** *и. мәгъ.* Билгеле бер дәүләт, монарх кул астындагы кеше; подданный. *Тугры табигъ*

**ТАБИГЪЛЫК** *и.* Билгеле бер дәүләткә караган булу, билгеле дәүләтнең гражданы, подданные булу. *Англия табигълыгында булу*

**ТАБИГЫЙ** *с.* **1.** 1) Табигатькә (*1–2, 4 мәгъ.*) бәйле; табигатьтә булган; табигать тарафыннан барлыкка китерелгән. *Кояш, Ай, йолдызлар, Һава, Җил, Җир, Ут, Су, Яңгыр, башка бик күп галәми, табигый җисемнәр, күренешләр, ияләр дә Күк Тәңре карамагында икән.* Г.Гыйльманов. *--- ясалма агачлык чын, табигый урман шикелле күкрәп утырачак!* В.Имамов

2) Табигатьтәге геофизик, климатик һ.б.ш. күренешләр белән бәйле. *Әгәр эш турында документ табигый афәт (җир тетрәү, су басу, көчле давыл, янгын һәм башка шундый сәбәпләр) аркасында югалса һәм аларны яңадан тергезеп булмаса, --- ике яки күбрәк шаһитның күрсәтмәләре нигезендә [закон] эш стажын раслауны рөхсәт итә.* Өмет

3) Организмның биологик үзенчәлекләре белән бәйле; шуның ихтыяҗлары белән аңлатылган. *Тоткын парашага килде, торуы шул кечкенә табигый йомыш өчен икән.* Г.Ибраһимов. *Кызда табигый инстинкт сөйләшә иде, гакыл түгел.* Р.Мөхәммәдиев

4) Тумыштан, нәселдән килә торган. *Ул җырга, биюгә оста, мандолина чиертергә дә өйрәнеп алды, табигый зәвыгы һәм мөлаемлыгы белән аерылып тора.* А.Тимергалин. *Расих иптәш Сабировның кечкенә генә бер табигый кимчелеге барын күпләр белмидер әле.* Т.Нәҗмиев

5) Табигать кануннары нигезендә бара торган, биологик закончалык булып торган. *Алар арасында табигать шартларына тагын да җайлашу, камилләшү, нәселне саклау һәм тагын да яхшырту әнә шундый табигый сайланыш белән бара.* А.Хәсәнов

6) Табигатьтән (*1 мәгъ.*) табыла торган, табигатьтә булган нәрсәләрдән ясалган; натураль. *Аңа дарчин төсендәге табигый буяу белән төрле бизәкләр төшерелгән.* Р.Ахунҗанова. *«Район өчен, бигрәк тә табигый газ кертүдә күп эшләде бит», – дип тә өстәде.* Т.Нәҗмиев

7) Нәрсәнең дә булса табигатенә (*8 мәгъ.*) хас булган, асылын тәшкил иткән, гадәти, үзенеке. *Димәк, телдә стилистик чара буларак сүзләр, әйләнмәләр кабатланганда, икенче тел формаларына механик рәвештә иярмичә, туган телдәге сөйләмнең табигый агышын тоеп һәм аны бозмаслык итеп, иҗади эшләргә кирәк.* Р.Юсупов

8) Мөнәсәбәт, холык, кыланыш, үз-үзен тотыш һ.б.ш.да ясалмалылык булмаган, беркатлы, эчкерсез, саф, самими. --- *һәрвакыт үзенең табигый хәлендә, ләкин табигый хәленә аның бәйсезлек һәм үз-үзенә ышану хас булса кирәк, һәркем белән бертөсле, алдына килүченең йөзенә күтәрелеп карарга һәм сүзенә җавап бирергә иренми, кыскасы, чын кеше һәм әйбәт директор булырга тиеш.* Ә.Еники. *Кунакчыллыклары табигый, эчкерсез иде.* Р.Газизов

9) Барлыкка килүе көтелгән, мантыйклы, закончалыклы булган. --- *атлар бар җирдә малай кешенең чуалуы – бик табигый нәрсә, аңа юньләп игътибар да итмиләр.* Ә.Еники. *Шуңа күрә «Татар әдәбияты дөньясы» сериясенең беренче томлыгы булган Аяз Гыйләҗевнең рус телендәге китабына кереш сүзне Чыңгыз Айтматов язуы – бик табигый хәл* ---. Мәгариф

10) Гадәти, гадәттәге, һәрвакыттагы. *Чөнки тормышның табигый агышын үзгәртергә хакыбыз юк.* Ф.Баттал. *Концерт табигый агымда барды.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Гади рәвештә, ясалма итмичә. --- *уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә, ихтыярсыз, янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды.* Ә.Еники. *– Истә, Вилдан, көн дә истә, – диде ул пышылдап һәм көче җиткәнчә табигый елмаерга тырышып.* Ф.Садриев

2) Үз җае белән, гадәттәгечә; гадәти рәвештә. *Аның каушамавын, үз-үзен бик табигый тотуын күреп, Суфия ханым җиңел сулап куя: хәзер инде ул кызы уенда хур булыр дип курыкмый.* Г.Әпсәләмов. *Анысы ничектер табигый кабул ителә, ир кешегә бу килешеп тора иде сыман.* М.Маликова

**3.** *хәб. функ.* Гадәти булу, мантыйклы күренү. *Яшь чакта башны югалтып хисләргә бирелү табигый.* М.Маликова. *Билгеле, ара-тирә кылган гамәлләр, сайлаган юнәлешләр хакында бәхәсләр кузгалуы да бик табигый.* С.Хафизов

**4.** *кер. сүз функ.* Әлбәттә, билгеле, һичшиксез. *Табигый, әңгәмәдә катнашучыларның күбесе читтән килгән кеше булганлыктан, Казан белән башка бер губерна шәһәре арасындагы аерманы бигүк чамалап бетермиләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Табигый, без театрны бик тә ярата идек, аның могҗизасы каршында хәзер дә баш иябез.* И.Гыйләҗев

**ТАБИГЫЙЛӘНҮ** *ф.* Табигый булып китү; ясалмалыктан котылу. *Меңәр ел халык телендә чарланган ул сүзләр шулкадәр табигыйләнгән, аларга артык игътибар итүче дә юк…* Р.Зәйдулла

**Табигыйләнә бару** Торган саен тагын да табигыйләнү

**Табигыйләнә башлау** Табигыйләнүгә таба бару

**Табигыйләнә төшү** Берникадәр табигыйләнү; тагын да табигыйләнү

**Табигыйләнеп китү** Күзгә күренеп табигыйләнү

**ТАБИГЫЙЛЕК** *и.* 1) Чынлык, дөреслек, тормышчанлык; чынбарлыкка туры килү. *Җиңел кәсеп итәргә ниятләгән умартачылар үз кортларына шикәр ашата* ---. *Табигыйлек һәм балга хас исе булсын өчен, бу суррогатка табигыен өстиләр.* З.Фәтхуллин

2) Ясалмалыктан азат булу; гадилек, самимилек. *– Мәрвәр ханым ничек соң, исән-саумы? – диде Ләйлә ханым, шундый ук эчкерсез табигыйлек белән.* Ә.Еники

**ТАБИГЫЯТ** *җый. и. гар. иск.* 1) Табигатьнең төрле чагылышлары, төрле күренешләре; төрле формалардагы табигать

2) Табигать турындагы фән, табигать белеме. *Мәдрәсәләрдә рус теле, хисап, җәгърафия, һәндәсә, табигыят, тарих вә башкалар илә дә таныштым.* Гасырлар авазы

**ТАБИКМӘК** *и. сөйл.* 1) Әче камырдан табага җәеп пешерелә торган, беленнән калынрак камыр азыгы. --- *ул кичен казанда кайнаган каз ите, каз мае белән майланган табикмәк исенең өй эченә генә түгел, бөтен урамга таралуы... авыл халкы күңеленә сөйләп тә, язып та аңлатып бетерә алмаслык шатлык өсти, ләззәт бирә.* С.Поварисов

2) *диал.* Бодай кабартмасы

3) *диал.* Карабодай, тары яки борчак оныннан пешерелгән күмәч. *Мескен Зөләйха апа, капка төбенә чыгып я күпер өстенә үк менеп, малаен каршы ала, кулында әрчелгән күкәй, карабодай табикмәге яки бер кыерчык ипи иде.* Д.Салихов

**ТАБЛЕ́ТКА** *и. рус* 1) Кечкенә яссы түгәрәк, төймә формасындагы берәр нәрсә. *Аннары таблетка формасындагы биш төрле химик матдә салабыз.* Л.Заһидуллина. *Термопластик материал гранула, таблетка яисә онта хәлендә тутыргыч бүрәнкә аркылы цилиндрга салына.* Төзү материаллары. *Махсус таблетка белән кайнар ризык пешереп була торган бу җайланманы ул гастрольләргә һәрчак үзе белән ала.* Шәһри Казан

2) Шундый формада прессланган бер дозалык порошоктан гыйбарәт дару формасы. *Көн саен иртән бер таблетка кабул итсәң, йөрәк үлгәннән соң да ике сәгать эшләп тора.* Т.Миңнуллин. *Күрсәтергә теләмәгән сыман читкә борылып, сәдәп хәтле генә ак таблетка йота.* С.Сабиров

3) *сөйл.* Яссы түбәле, озынча формалы хатын-кыз эшләпәсе. *Миңа таблетка килешә. Вуальле таблетка*

**ТАБЛЕ́ТКАЛЫ** *с.* 1) Таблеткасы булган. *Таблеткалы кап*

2) Таблетка рәвешендә булган, таблетка формасына китерелгән. *Башлыча алар – парацетамол, арбидол, амоксицилин кебек таблеткалы дарулар, алар бу яшьтәге балаларга бик үк туры килми.* Минзәлә

**ТАБЛЕ́ТКАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Таблеткасы булмаган; таблеткалары беткән. *Таблеткасыз блистер*

2) Таблеткалар белән бәйле булмаган; таблетка кулланмаган. *Анастасия Николаевна бирердә дә сәламәтләндерү алымын тапкан: 18 хатын-кыздан торган «Сәламәтлек» төркеме җыйган, алар «Таблеткасыз тормыш» девизы белән атнага өч мәртәбә спорткомплекска йөриләр.* Яңа Чишмә хәбәрләре

**2.** *рәв. мәгъ.* Таблетка кулланмыйча. *Таблеткасыз нинди иҗат, ди!* М.Кәбиров

**ТАБЛИ́ЦА** *и. лат.* Саннар белән белдерелгән, билгеле эзлеклелектә графаларга урнаштырылган нинди да булса мәгълүмат; җәдвәл. *Карлыган яфрагы кушып пешерелгән чәйгә чынаягына берәр кашык гольштино-фриз сөте салып рәхәтләнеп утырганда, минем әңгәмәдәшләр тиз генә менә мондый таблица эшләделәр.* М.Мәһдиев. *Буй һәм авырлык үлчәгечләр, күзне тикшерә торган таблица.* Х.Камалов

**ТАБЛИ́ЦАЛЫ** *с.* 1) Таблицасы булган

2) Таблица рәвешендә бирелгән, таблицага салынган, таблица формасына салынган

**ТАБЛО** *и. фр.* Ерактан күренерлек итеп, вокзал, аэропорт һ.б.ш. җәмәгать урыннарында урнаштырылган электрон белдерүләр тактасы. *Анда автобусларның хәрәкәтен күзәтергә мөмкинлек биргән табло да булырга тиеш.* И.Фәйзрахманов. *Казанның Ирек һәм Тукай мәйданнарындагы тукталышларга бу көннәрдә электрон таблолар урнаштырылачак.* Татарстан яшьләре

**ТА́БОР** *и. төрки* 1) Бергә күчеп йөрүче чегәннәрнең берничә гаиләсеннән торган төркем. *Юк, мин чегән таборына ияреп китәм...* А.Хәсәнов. *Тимер юл янында урнашкан татар авылын узып, ике чакрым җир үткәч, табор җәйләүгә туктады.* И.Диндаров

2) Шуларның вакытлыча яшәү өчен тукталган урыны. *Карасёв соңыннан шул урынны барып күрсәтте. Элек бу төштә биш чегән семьясының таборы торган булган.* Н.Ямалиев

3) *сөйл.* Берәр урынга килеп урнашкан зур халык төркеме; әлеге урын үзе. *Ниһаять, юлчылар хәлдән таялар, шау-шулы бер табор булып тукталып калалар.* Робинзон эзләреннән. *Әле Парин урамы белән «Рамстор» арасындагы посадкада «бомжлар таборы» барлыкка килгән, ди.* Татарстан яшьләре

4) *тар.* Россиядә XV–XVII гасырларда походтагы гаскәрнең олаудагы арбалар белән уратып алынган вакытлыча урнашу урыны; ныгытылган хәрби лагерь. *Арбалардан боҗра сыман ныгытма – табор яисә «курень» кору скифларда да була.* Н.Фәттах. *Казаклар таборы*

5) *тар.* Әлеге лагерьны тәшкил иткән, шуңа сыярлык гаскәрдән торган хәрби берәмлек. *Вә һәм сарайның тышкы ягыннан берничә табор гаскәр сарайны ихата кыйлып, кылычлар ялангачлап, мылтыкларын корып тордылар.* К.Насыйри

6) Авыл тышында, кырда, урманда эшләүчеләрнең станы. *Көзге эшкә йомгак ясагач та кырда, таборда, Колхоз җыяр данлы батырларын шушы табынга ---.* М.Җәлил. *Чуваш таборларына барып чыгам. (Алар, шунда кунып, печән әзерләп яталар иде.)* Өмет

7) *диал.* Туплавык. *Таборга төш. Ала тайны мен.* З.Зәйнуллин

**ТАБУ** I *ф.* 1) Кирәкле, файдалы, кызыклы һ.б.ш. берәр нәрсәне күрү, үзенә алу яки кайдалыгын хәтерләп калу. *Борын-борын заманда, кешеләр әле агачка, ташка табынган чорда, бер адәм, аудан кайтышлый, тимердән ясалган бер хикмәтле әйбер табып ала.* М.Мәһдиев. *Бервакыт Аю урманда бер көмеш тәңкә табып алган.* Г.Гыйльманов

2) Кем дә булса югалткан, онытып калдырган нәрсәгә очраклы рәвештә тап булу. *--- бездә бит чак кына бер яхшылык эшләр хәл юк, хәзер дилбегә буе итеп газетага язып чыгалар. Берәрсенең онытылып калган сәгатен табып хуҗасына тапшырсаң да, трамвайда картларга урын бирсәң дә ---.* Ф.Яруллин

3) Көтмәгәндә кемне яки нәрсәне очрату, юлыгу, тап булу. *Мең сагыштан телгәләнгән йөрәк Уйламаган җирдә тапты сине.* Ф.Гыйләҗев. *– Ә бу кешене мин беләм, – диде Әхмәт, көтмәгәндә алтын тапкандай шатланып. – Ул – татар.* М.Кәбиров

4) Югалган яки яшерелгән нәрсәне махсус эзләп, кайда икәнен белү, билгеләү. *Яшерелгән байлыкны, революция елларында табып, дәүләткә тапшырган булулары бар.* А.Тимергалин. *Газзәбануның бөтен уе тизрәк төргәктәге хатны табып уку иде.* Г.Галиева

5) Кызыксынып, кирәксенеп, махсус эзләгән кемгә яки нәрсәгә тап булу, аны күрү, ачу. *Роберт дустымның хәлләре ничек икәнен сорашмакчы булып, институтта эзләштереп карасам да, табып булмады.* В.Нуруллин. *Йөреп арыгач, табып булмас ахры, дигәндә генә, эзләгән чардуганына юлыкты.* Н.Хәсәнов

6) Нәрсәне дә булса кулга төшерү, юнәтү, кайдан да булса эшләп яки сатып алу. *Кибеттән кибеткә йөри торгач, бүләкнең менә дигәнен тапты каенана.* Ф.Яруллин. *Бөтен ярминкәне бетереп эзләсәң дә мондый затлы муенсаны таба алмассың.* А.Гадел

7) *махс.* Уйланулар, тикшеренүләр, эзләнүләр нәтиҗәсендәниндидер ачыш ясау, кирәкле, әһәмиятле фикергә килү. *Иң күренекле акыл ияләре ике мең ел буена эзләп-эзләп тә таба алмаган гүзәл формула иде ул!* А.Тимергалин. *Эдуард тагын әллә нинди машиналар уйлап табар әле...* А.Гыймадиев

8) *махс.* Төрле яктан уйлап, тикшереп, берәр нәрсәне хәл итү, билгеле нәтиҗәгә килү, чишелеш юлын күрү, файдалы киңәш бирү, уңышлы фикер әйтү, дөрес юл күрсәтү. *Апай, шкафка сөялеп, табышмак әйтергә тотынды: – Җомак әйтәм, җөмен тап! – диде.* Г.Бәширов

9) *мат.* Исәпләп чыгару. *Бу картлар, баксаң, алгебраның бер бүлеген өйрәнеп, санның кубын табып утырганнар икән.* М.Мәһдиев. *Сумманы табу*

10) *махс.* Билгеле үзенчәлекләреннән чыгып ачыклау, аеру, билгеләү. *Таймасның тизрәк картадан карап, Пулководан бер сәгать унбиш минутлы меридианда урнашкан җирне табасы килә иде.* А.Тимергалин. *Җөмләнең иярчен кисәкләрен табу*

11) Махсус эзләнүләр нәтиҗәсендә нәрсәнең дә булса чынлыкта булуын ачыклау, дәлилләү, раслау. *Аның байлыгын, сирәк очрый торган үсемлекләрен табарга, билгеләргә тиешбез.* Х.Ибраһим

12) Бала тудыру. *Баланы да законлы иреннән табачак.* Н.Гыйматдинова. *Ә мин сиңа тупырдап торган әллә ничә малай табып бирәчәкмен.* Г.Галиева

13) *махс.* Чыгару, җитештерү (табигый байлыклар тур.). *Ә шәһәрдә шикәр комын каян алалар икән? Нефть кебек*

*җир астыннан гына табалар микән?* Мөҗәһит. *Бу шахталарда ташкүмер табалар*

14) *махс.* Алу, бүлеп чыгару. *Эфир майларын төрле үсемлекләрдән табалар*

15) *күч.* Казану, кулга төшерү, эшләп алу, булдыру (акча, матди байлык тур.). *Барый ага бүрек тегә, бүрек сата, Имаметдин имин генә итек баса. Такта ярып, акча табып йөри күпләр, Калганнары төрле җирдә начальниклар.* Г.Афзал. *Ашыйсы ризыгыңны уннарча чакрымнар әлсерәп чабып табарга кирәк.* А.Хәсәнов

16) *күч.* Берәр эш-гамәл, максат өчен иң уңайлы вакыт, юл, мөмкинлек сайлау, форсаттан файдалану. *Син, Нәзир дус, ничек тә вакыт табып килеп чык инде.* Ф.Яруллин. *Нургали артыннан хат җибәрергә әмәлен таба күр, яме.* Г.Галиева

17) *күч.* Казану, яулау, ирешү, билгеле яктан танылу (уңыш, дәрәҗә һ.б.ш. тур). *Ахыр бу шәһәрдә шөһрәт тапты.* К.Насыйри. --- *донос дигәч, минем күңелгә донос белән шөһрәт тапкан кешеләрнең һәммәсе килделәр.* Г.Исхакый

18) *күч.* Дучар булу, юлыгу, үз башына төшкәнне кабул итү, билгеле хәлгә төшү, тару. *Күрән би үзенең үлемен аяк астыннан тапты.* Н.Фәттах. *Һәм, чыннан да, нәфесен баса алмаучы һәр сабырсыз үлемен таба торды.* Н.Сәйяр

19) *күч.* Нәрсәдер кемгә дә булса насыйп булу, туры килү, өлешенә чыгу. *Беркөнне шатлык Шәяхмәтнең дә ишеген тапты.* М.Мәһдиев. *Еллар үтеп, дөньялар тынычлангач кына, тере вакытта иясен таба алмаган орден, бик күп җирләрне урап, Нурмигөл түтинең кулына килеп керә.* Ф.Яруллин

20) *күч.* Берәр сыйфат, белге, үзенчәлек һ.б.ш.лар нәрсәдәдер чагылу, күренү. *Шуның өстенә, «кырык» сүзе кеше тормышының бик күп тармакларында, матди һәм рухи дөньясында чагылыш тапкан.* М.Мәһдиев

21) *күч.* Берәр нәрсәне уңай тәэсир чыганагы итеп күрү, шулай дип кабул итү. *Көндәлек тормыштан ямь-тәм, ләззәт табып яшәү әнә шундый гүзәл мизгелләрдән туадыр...* А.Хәсәнов. *Мин әйтәм, тукта әле, яшьләр янына барыйм, сез монда мәзәк табып рәхәтләнеп көлешәсез.* А.Гадел

22) *күч.* Берәр нәрсәгә карата билгеле фикердә, караштa, мөнәсәбәттә булу, шул турыда билгеле хөкем чыгару; раслау. --- *март аенда гына комиссия үттем, һәм анда мине хәтта диңгез флотында хезмәт итәргә дә яраклы дип таптылар лабаса!* В.Нуруллин. *Хәзерлегe яхшы булгандырмы, Казанда калу теләге чиксез зурлыктанмы, ул шундый тырышып укыган булып чыктымы, гимназияләрдән килгән бай малайларын да уздырып, йөзләгән кеше арасыннан бушлай уку хокукы бирә торган өч стипендиянең берсенә лаек дип табылды.* Р.Мөхәммәдиев

23) **таптың** *күч. ирон.* Кемнең дә булса берәр төрле эше, шөгыле, сүзе, фикере көтелгәнчә булмауны, уңышсыз мисал булуны, чынлыкка туры килмәүне белдерә. *– Моцартлар, Шубертлар, Глинкалар беркайда да эшләмәгән, шулай да менә дигән итеп яшәгәннәр, иҗат иткәннәр. – Таптың чагыштырыр нәрсә.* Р.Вәлиев

24) **тапкан** *күч.* Кемнең дә булса берәр эшне, шөгыль, сүз һ.б.ш.ны кабатлавын, артык мавыгуын өнәп бетермичә, ачуланып әйтелә. *Курай, курай, имеш, тапканнар бер курай.* Ф.Әмирхан. *Тапкан бер сүз: балалар да балалар.* Г.Ибраһимов

◊ **Тапкан бер** Табылганнарның барысын да, һәммәсен. *Хатыннар халкы бала таба, тапкан бер ир баланы Үрөскан гаскәренә бирә бара.* Р.Батулла. --- *бала-чагалар тапкан бер савытын күтәреп, каен суына каенлыкка чапты.* З.Кадыйрова. **Тапма да, бүлешмә дә** «Бу кеше белән эш итү авыр, кыен, мондый кешегә эшең төшмәсен» мәгънәсендә. *Усал белән тапма да, бүлешмә дә.* Т.Гыйззәт

**Таба башлау** Хәл табу ягына үзгәрү; табу очраклары булу. *Менә, ниһаять, күңелем тынычлык таба башлады.* К.Тимбикова. *Иртә-кич ире рухына багышлап догалар укып, юаныч таба башлый.* Т.Нәҗмиев

**Таба тору** Әледән-әле, һаман табу. *Ә инде эчү әтисенең гадәтенә кереп киткәч дәшми кала алмады, ләкин ата кеше һәр очракта кызы алдында акланырга сәбәбен таба торды.* Ф.Яруллин. *Сулимов, колхозга килгән саен, Назыйм абыйның вак-төяк кимчелеген таба торды, шуның белән кәефен кыра торды.* М.Вәлиев

**Табып алу** Бик тиз табу; бер табып, шуны югалтмыйча дәвам итү. *Медведев та алай тиз генә төзәлеп китә алмас, ләкин класс җитәкчесе аның кирәкле кылын табып алган инде.* Л.Ихсанова. *Ул арада Нурулла да йөрәген кузгаткан хисләр ташкынының бер җаен, тәртибен табып алды ---.* М.Вәлиев

**Табып бару** Эзлекле рәвештә табу; һәр очракта табу. *– Төшереп котылу ягын карамыйсың, бөтенесен табып барасың, – дигән иде.* Г.Галиева. *Бүгенгә кадәр гел чарасын табып бардылар*

**Табып бетерү** Бик күп, көтелмәгән күләмдә табу, көтелмәгән җирдән табу; барысын да табу. *– Гамил абый, бу амбар кенәгәләрен каян табып бетерәсең? – дигән идем ---.* Р.Фәйзуллин. *Җантай әбинең йортына көндез генә түгел, төнлә дә киләләр. Кайдан имтом табып бетерәдер.* Р.Зәйдулла

**Табып бирү** Башка берәү өчен табу. *Имеш, әле апаларының кассага салмаган акчасы да булгандыр, табып бир, янәсе.* Ә.Баян. *Мин моңа «ч» хәрефенә башланган егермедән артык кушамат табып бирдем.* С.Шакиров

**Табып йөрү** Берара табу; гел табу; шактый вакыт табу. *Ул үзе дә кайчандыр берәүне газап утларына салган, аның сөеклесен үзенә каратып тота алуы белән горурланып, шуннан тәм табып йөргән иде.* Айгизә. --- *дөнья рәхәтлегеннән балаларча тәм табып йөргән әбисенең болай ачуланган чагын моңа хәтле күргәне булмаган Илсөя дә боекты.* М.Әхмәтшина

**Табып җиткерү** Тиешле күләмдә, тиешле вакытка табу. *Һаман хуш аваз эстәр, инде ул эстәгән саен шигырь табып җиткермәк тә мөшкел булды ---.* К.Насыйри. *Күкрәк сөте булсын, ә аны һаман саен табып җиткереп булмый.* Х.Камалов

**Табып карау** Табарга тырышу. *Исем-фамилиясе дә билгесез кешене Казан хәтле Казанда эзләп табып*

*кара!* Г.Әпсәләмов. *Я ярый, синең соравыңа бергәләп җавап табып карыйк.* Ф.Яруллин

**Табып китү** Табып, шуны саклау, югалтмау, эзлекле дәвам итү. *Һәрхәлдә, бу салкынлык өчен Рәфис, беренче чиратта, үзен битәрли, алар белән тәүге очрашуда ук уртак тел табып китә алмавына газаплана иде.* А.Вергазов

**Табып кую** Табып әзер итү, алдан ук табу; кинәт табу. *Бу китапларны мин сиңа табып куярмын.* А.Тимергалин. *[Галәветдин:] Хәзер, хәзер, тональностен генә табып куям. Ничек башлана соң әле?* Аманулла. *Анысы, хәер, белеп булмый, бәлки, табып та куярсың.* Г.Каюмов

**Табып тору** Әлегә, күпмедер вакытка гына, вакытлыча табу; даими яки әледән-әле табу. *Борын заман бик белемле табиб торган, Сырхауларга әйбәт дару табып торган.* Г.Афзал. --- *бераз ял итеп, иректә йөреп кайтыйк дип килгән чакларында, Халигулла аларга эшне табып кына тора иде.* Ә.Сафиуллин

**Табып чыгару** Әллә кайлардан табу. *Кыз нишләргә белми, һаман ай азагын көтәргә кушып, мең төрле сәбәп табып чыгара.* Х.Камалов. *Ул Акмулланың биографиясенә кагылышлы фактларны аның шигырьләреннән табып чыгара.* Э.Галиева

**ТАБУ** II *и. полинез.* 1) Башлыча борынгы кабиләләрдә нинди дә булса сүзләрне, предмет яки эш-хәрәкәтне тыю йоласы. *Бу илләрдә сары төскә табу булган: гади халыкка сары төстә киенергә дә ярамаган, сары төскә өйләрне дә, башка әйберләрне дә буярга рөхсәт булмаган.* Татар, уян!

2) Тыелган, рөхсәт ителмәгән шундый нәрсә. *Әмма мәшһүр Туфанның бу әсәренә кагылырга ярамый торган әйбер – табу итеп карау дөрес булмас иде.* Безнең гәҗит

3) Гомумән, тыю, рөхсәт итмәү күренеше, гамәле. *Безнең өйдә гомумән сүгенүләргә, тәмәке тартуларга табу салынган булганлыктан, татарча да сүгенә белми идем.* Ф.Яруллин

**ТАБУН** *и.* Ат көтүе, өер. *Еракта-еракта, кичке шәфәкъ аллыгыннан ут дөрләгән офыкта, атлар табуны.* Н.Нәҗми. *Синең җәйләүләреңдә бүген меңәрләгән атлы табуннарың йөри, Алдар тархан.* В.Имамов

**ТАБУ́Н-ТАБУН** *рәв.* Табунлап, табуннар рәвешендә

**ТАБУРЕТ** *и. фр.* Квадрат яки түгәрәк каты утыргычлы артсыз урындык. *Безнең табурет Маяковскийның ике метрлы буе өчен шактый тәбәнәк булса да, тезләре ничектер югары күтәрелеп торса да, Маяковский үзе(н) бик җайлы урында сизә кебек тоела.* Х.Туфан. *Шәрифҗан Якубның агарып калган йөзенә карады, табуретны тартып, карават каршына утырды.* И.Гази

**ТАБУРЕ́ТКА** *и. рус к.* **табурет**. *Хәрби форманы алган көнне кич йокыга яттык, һәркем, старшина кушуы буенча, кием-салымын табуретка өстенә төреп рәтләп куйды, старшина карап чыкты.* М.Мәһдиев. *– Юк-юк, ишек катыннан түгел, түрдән, түрдән утырасың, – дип чат ябышты Фатыйма апа, кунагының кыяр-кыймас кына табуреткага килеп утыруын ошатмыйча.* Р.Мөхәммәдиев

**ТАБУТ** *и. гар.* Мәетне салып җирләү өчен капкачлы озынча әрҗә. *Кире кайтып килгәндә, Гафури урамындагы бер йортның капка баганасына терәлгән табут капкачын күргәч, сискәнеп китте.* А.Гыйләҗев. *Институтның актлар залыннан урындыкларны алганнар, уртасына биек ятак ясап, табут куйганнар.* М.Маликова

**ТАБУТЛАП** *рәв.* Табутка салып. *Табутлап җирләү*

**ТАБУТЧЫ** *и.* Табут ясаучы. *Чәч алучы белән табутчының Итекләре бер үк тупсада.* М.Җәлил. *Шайтан алгыры, кемдер үлгән, ә Табутчы Коля бистәдә юк иде.* Н.Гыйматдинова

**ТАБЫЛДЫК** *с.* **1.** 1) Кем дә булса онытып яки төшереп калдырган җирдән табып алынган. *Табылдык малга ия күп.* Мәкаль. *Кичен, Габдеррәшит бабай кайткач, табылдык йөзек турында сүз барды.* А.Тимергалин. *Малайлар бабаларыннан яшереп маташуны кирәк санамадылар, табылдык хатлар турында бәйнәбәйнә сөйләп бирделәр.* А.Гыймадиев

2) Зинадан туган яки ата-анасы билгесез булган. *Мәхдүмгә бирмичә, ата-анасыз, җиде яттан туган табылдык Исмәгыйльгә кыз бирәләр.* К.Тинчурин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кем дә булса онытып яки төшереп калдырган җирдән табып алынган нәрсә. *Хуҗасы күренмәде, чөнки табылдык үз ишегем төбендә иде, тәгаен, кесәдән бияләйне алганда ияреп чыгып, үземнеке төшеп калгандыр.* Р.Шәяхмәтова. *Уенда каймак та, эремчек тә калмады, тыштан хәтәр затлы күренгән табылдык бар булмышын билгеле.* А.Әхмәтгалиева

2) Ата-анасы баш тартып калдырып киткән бала. *Авыл халкы Зимагур Булатта яшәп ятучы табылдык малайга әллә нәрсә игътибар итмәде, чөнки һәркемнең үз хәле хәл иде.* Ф.Бәйрәмова. *Фәйрүзә бу аһлы, зарлы сүзне әллә табылдык балага карата, әллә үзләренең бәхетсез кызларына карата әйтте – төгәл генә белеми калды ---.* Г.Гыйльманов

3) Никахтан тыш туган бала. *Табылдыктыр әле үзең?* М.Җәлил

**ТАБЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **табу** I. *Нефть табыла шушы җирләрдә.* Н.Арсланов. *Өстәвенә, ул тирәләрдә энҗе-мәрҗән күп табыла.* И.Хуҗин. *Исәпләүләр нәтиҗәсендә максималь бөгелеш табыла.* Фән һәм тел

2) Эзләгән, көтелгән, кирәк булган нәрсә очрау, килеп чыгу, пәйда булу. *Тентү вакытында кәгазьләр арасыннан бик күп шәкерт җырлары табыла.* Р.Батулла. *Археологик казулар вакытында балчыктан ясалган савыт-саба һәм аларның ватыклары бик күп табыла.* Р.Фәхретдинов

3) Табу мөмкинлеге, ихтималы булу. *Сәбәбе дә кирәк түгел, теләк булса, сәбәп табыла ул!* Ф.Яхин. *Алучысы булса, сатучысы табыла.* Шәһри Казан

**Табыла бару** Бер-бер артлы табылу. *Сугыштан соң күпме гомер үтеп тә җинаятьчеләрнең һаман да табыла баруы, суд алдына бастырыла торулары хакында сүз кузгаттым.* М.Хәсәнов

**Табыла башлау** Табылу очраклары булу. --- *Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллинага бирелгән бүләкләрне күпсенүчеләр табыла башлады.* Татарстан яшьләре

**Табыла тору** Һаман-һаман табылу; кирәк саен табылу

**Табылып бетү** Барысы да табылу; тулысынча табылу. *Бөтен кешегә дә күп акчалы, чиста эш каян гына табылып бетсен.* Шәһри Казан. *Ул вакыттагы сөенечләргә газета битләрендә урын табылып бетте микән?* Безнең гәҗит

**Табылып кую** Шундук табылу; көтмәгәндә табылу. *– Бәлки, әле энекәшләрең дә табылып куяр?! – диеп, Изаел артык өметсез әйтеп салды.* Р.Гаязетдин. *Бихисап сорауларына да җаваплар шундук табылып куя.* Безнең гәҗит

**Табылып тору** Даими яки әледәнәле табылу. *Ә берәрсенә утын яки печән алып кайтырга туры килсә, өйгә чакырып сыйлыйлар. Ә эш гел табылып торды.* Ф.Яруллин. *Һәр бәхетсезлеккә сәбәп табылып тора.* М.Маликова

**ТАБЫН** I *и.* 1) Төрле ризыклар, савыт-саба, аш-су кирәк-яраклары һ.б.ш. куеп әзерләнгән ашау урыны, корылган өстәл. *Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфетлар китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды.* Ә.Еники. *Әллә табын бик такыр булганга шулай кашларын җимереп утырамы бу тегүче?* Г.Бәширов

2) Күмәкләшеп ашау өчен, шундый өстәл тирәсенә утырган бер төркем кеше. *Менә Ходайның рәхмәте, көтмәгәндә генә ул [Акъәби] иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле.* Ә.Еники. *Җыр тәмамлангач, көчле тәэсирдән исләренә килә алмагандай, бер генә мизгелгә тынып тордылар, аннан бөтен табын дәррәү кубып, гөр килеп шаулаша башладылар.* М.Хәсәнов

3) Шундый төркем рәвешендә, бергәләшеп ашау күренеше; шунда үткән вакыт. *Утырдык без табынга, Җыелып, тыгыз булып.* Ә.Исхак. *Ул көнне табын түгәрәк, ризык мул, күңелләр күтәренке булды.* М.Хәсәнов

4) Юлда йөргәндә, эш урынында һ.б.ш. очракларда бергә тукланырга килешкән кешеләр төркеме. *Һәр арбада өчәр-дүртәр утырып баручы татар, чуваш, марилар, мукшылар үз табыннарының яз көнге кичке ашлары турында сөйләшә башладылар.* А.Таһиров

5) *күч.* Дусларча сөйләшеп торган кешеләр җыелмасы, бер компания. *Мин --- кешеләр табынына тиз катнаша алмау сыйфатым белән дә риза түгел.* К.Басыйров. *Ишектән бөгелеп кергән, башы түшәмгә терәлгән төнге кунакны абайлагач, шау-гөр килгән табын сүрелә төште, ишек ягына аркаларын куеп утыручылар да борылып-борылып шомлы карап алгач, тәмам тынып калдылар.* Л.Зөлкарнәй

6) Кунак, сый мәҗлесе. *Табын инде шактый кызган, ашыйлар, эчәләр.* З.Хәким. *Әмма бер табын белән генә бетми: туган-тумачаны, хезмәттәшләрне аерым-аерым чакырмый булмый.* Кызыл таң

7) Бер өстәл тирәсенә сыярлык кешеләр тәшкил иткән кунак-төшемне исәпләү берәмлеге. *Әле онытмаска кирәк, Мәскәү өстендә бер-ике табын хатыннар уздырып алырга кирәк.* Г.Камал. *Утырсак, үзебез дә бер табын булабыз хәзер, дип уйлады Гадилә.* Н.Кәримова

**ТАБЫН** II *и. к.* **табун**. *Яхшы айгыр табын ташламас.* Мәкаль

**ТАБЫНГАНЛЫК** *и.* Берәр затка артык табыну, буйсыну, мөкиббән китү күренеше

**ТАБЫНДАР** *и. иск.* Табын иясе, мәҗлес хуҗасы. *Кунак булсаң да, табындарга табынма.* Мәкаль

**ТАБЫНДАШ** *и.* Кемнәр белән булса да бергәләп, бер табыннан ашаучы кеше. *Һәр табындаш тугандаш түгел.* Мәкаль

**ТАБЫНДАШЛЫК** *и.* Табындаш булу; бергә ашау

**ТАБЫНДЫРУ** *ф.* Көчләп, берәр нәрсәсе белән кызыктырып, җәлеп итеп һ.б. рәвешле кемгә яки нәрсәгә дә булса табынырга мәҗбүр итү. *Бурыч басындыра, кылыч табындыра.* Мәкаль. *Бу әкияткә көчләп корал белән табындыру аркасында, күпме кан дәрьясы акты, күпме халыклар, үз йөзен, гореф-гадәтләрен җуеп, күндәм массага әверелделәр.* М.Галиев. *Карлыгач канатыдай кыйгач кашлары, күл камышыдай зифа буйлары кемнең генә башын әйләндермәс тә үзенә табындырмас икән.* Г.Хөсәенов

**Табындыра бару** Акрынлап табындыру

**Табындырып бетерү** Тулысынча табындыру

**Табындырып тору** Табындырган хәлдә тоту

**ТАБЫНЛЫ** *с.* 1) Табыны (I) булган, табын корылган, табын җәелгән. *Бәлеш исе еш чыккан, мул табынлы өйгә ират та сөенә-сөенә кайта бит ул!* Татарстан яшьләре. *Алтын көзнең мул табынлы чорында ел саен әлеге бәйрәм зурлап билгеләп үтелә.* Маяк

2) Табын (II) рәвешендәге, табынга (II) тупланган (атлар тур.)

**ТАБЫНЛЫК** *и.* **1.** Табын өчен әзерләнгән урын, табын буласы җир; табын тирәсе. *Идәнгә киез, аның өстенә авыл эше келәмнәр җәелгән; аның өстенә кара юрганнар түшәп, кечкенә табынлык ясаганнар.* Г.Ибраһимов. *Бу – колхозчыларны хәтфә чирәм җәелгән иркен табынлык янына чакыру иде.* С.Рафиков

**2.** *с. мәгъ.* Табын өчен билгеләнгән, шуңа кирәк булган, шуңа җитәрлек. *Җиз таз белән җиз комганнан кала бөтенесе бар: --- бер табынлык салфетка, ак самавыр, бик матур чәй сервизы, тутыкмас корычтан чәнечкепычаклар, аш тәлинкәләре, төрле савыт-сабалар...* Ә.Еники. *Корбан гаетендә бигрәк тә күңелле була: ел саен икешәр корбан чалдырып, өчәр табынлык аш үткәрәләр.* Ватаным Татарстан

**ТАБЫ́Н-ТАБЫН** *с.* **1.** Табыннар рәвешендәге; табыннарга урнашкан; табыннарга бүленгән. *Шулай ук, кешеләргә бурычы була торып, киенеп-ясанып йөрү, хатын һәм балаларын бизәндерү, йорт һәм җиһаз төзү, табын-табын халык җыеп сыйлау – эшне ахырын уйлап эшләмәү һәм бу хәдис шәриф өйрәткән ысулның киресе белән гамәл кылу була.* Р.Фәхретдин. *[Солдатның] ул хатыны икән тәмлетамак. Чакырганы – табын-табын кунак.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Табынлап; табыннар рәвешендә. *Табын-табын булып, күмәкләшеп утыралар.* А.Хәсәнов. *Әнә каен төпләрендә табын-табын булып утыра халык.* Ф.Мөслимова

**ТАБЫНУ** *ф.* 1) Раббы дип танылган затка гыйбадәт кылу. *Кам Аштабар, халыкны җыеп, тәңреләргә табына, илгә үләт чирен кертмәскә келәү әйтә.* А.Гадел. *Хәтта Борнаш сәет үзе дә,*

*Таштүбәдәге таш балбал янында яшертен корбан чалып, куйның канын туфракка сибә-сибә, мәҗүси таш сынга табынып кайткалый икән, дигән хәбәрләр бар.* Р.Батулла

2) Кемне яки нәрсәне дә булса илаһ урынына күрү, шундый мөнәсәбәт күрсәтү, шуңа буйсыну. *Сары металлга табындык, Табыну-ышану тарихыннан Баедык җилле генә.* Г.Афзал. *Алласыз әле кешеләр: Табыналар утка. Табына алар Кояшка, Табыналар Көнгә.* Г.Морат

3) *күч.* Төп игътибарны кемгә, нәрсәгә дә булса юнәлтү, шуның белән нык мавыгу, мөкиббән китү. --- *әле кичә генә үзләре көлгән, мәсхәрә иткән, рәнҗеткән кешеләргә табына башлыйлар.* А.Тимергалин

**Табына башлау** Табынырга тотыну. *Кичә таптаган аллаларга хәзер табына башладык...* Г.Ибраһимов. *Димәк, байтак конкрет мәгълүматлардан шундый бер ифрат та мөһим нәтиҗә ясарга мөмкин: беренче булып Кешелек дөньясы аллага түгел, алиһәгә табына башлый.* Ф.Урманчеев

**Табынып килү** Эзлекле рәвештә, бик күптәннән табыну. *Татар халкының үлемсезлеге һәм рухи баһадирлыгы – гасырлар буена табынып килгән исламдагы иманның кодрәтле булуында!* Ш.Абилов

**Табынып тору** Даими яки әледән-әле табыну; әле, хәзерге вакытта табыну

**Табынып яту** *сөйл.* Озак вакытлар табыну. *Ходайга ялварган сыман, ул Күчемгә читтән генә табынып ятмале син, борадәр.* В.Имамов

**ТАБЫНУЧЫ** *и.* Кемгә яки нәрсәгә табынган кеше. *Берәүләр кайчандыр, кайдадыр күргән зоопаркны искә ала, икенчеләр, үзләренең ау маҗараларын хәтерләп-сөйләп, тыңлаучыларны көлдерә, ә өченчеләр, сынга табынучылар кебек, тукталып, башларын иеп торалар.* И.Салахов. *XIX йөз һәм XX йөз башы дин белгечләре зәрдөштлектә торучыларны утка табынучылар дип кенә атаганнар.* Ф.Урманчеев

**ТАБЫНЧЫ** *и.* Табынга ашамлыкэчемлек китереп бирү, ризыкларны алмаштыру кебек эшләрдә хуҗага ярдәм итүче кеше. *Болар туралмаган иде, Фәйзулла мәзин белән Хаҗиморат гаҗәп бер осталык күрсәттеләр. Тизтиз пычак уйнатып, итне, бәрәңгене, салманы турап, кызу, кайнар шулпа өстәп, әзерләп куйдылар, икенче табынчы бүлә торды.* Г.Ибраһимов. *Табынчы кыз --- җитди генә сорап куйды: – Кем буласыз сез, апа?* Ә.Еники

**ТАБЫНЧЫЛЫК** *и.* Табынга савытсаба, аш-су китереп, табындашларга хезмәт күрсәтү эше. *Ул [Камилә] үзе табынчылык итә, аш сала, чәй ясый.* Г.Ибраһимов

**ТАБЫР** *и.* 1) *иск.* Утлап йөргән ат өере. *Атымны җибәрдем табырга, Маңгай ялын үрдем танырга.* Җыр. *Атымны җибәрдем табырга, Табырга гына түгел, табынга.* Җыр

2) *диал.* Гадәттә мал-туар, көтү җыела, туплана торган урын; туплау. *Бияне тотып, үзләре яткан табырга алып төштеләр.* З.Зәйнуллин

3) Табор. *Чегән табыры кебек, сез гел шулай гомергәме күчеп йөрерсез?* Г.Латыйп

4) *тар.* Хәрби лагерь

5) *диал.* Басуда күмәк эшләр вакытында килеп ял итү урыны

6) *күч.* Гомумән табырга, көтүгә охшаган, шуны хәтерләткән нәрсә. *Иңрәеп, ярсу чыбыркымны Бер шартлатсам әгәр, кыланып; Үрә баскан сүзләр табырында Шомырайта барсы колагын.* М.Галиев

**ТАБЫРЛАНУ** *ф.* Җыелышу, табыр хасил итү. *Табуннарда елкы сүз – Атларым, Табырлана елгыр тулпарларым.* М.Галиев

**Табырлана башлау** Табырланырга тотыну

**Табырланып бетү** Тулысынча табырлану

**Табырланып тору** Табырланган хәлдә булу

**ТАБЫРЛА́У** *ф.* Берәр урынны тоташ көтү, өер булып каплап алу; табыр итү. *Болыннарны атлар табырлаган, Бер җыр ишетелә табыннардан.* Г.Рәхим

**Табырлап алу** Тиз арада табырлау; тулысынча табырлау

**Табырлап бетерү** Тулысынча, тоташ табырлау

**ТАБЫШ** *и.* 1) Табып алынган нәрсә, табылдык. *Чемодан эчендә, иң өстә, фотоаппарат ята иде. Менә ичмасам табыш!* Х.Сарьян

2) Билгеле бер һөнәр яки кәсеп белән табылган мал, материаль кыйммәт. *Чыңгыз бабабыз әле өч гасыр элек үк вилаятьләрдән вә һәрбер игенчеһөнәрчедән табышларының уннан бер өлешен генә салымга җыйнауны канун итеп кертkән.* В.Имамов. *Җирсез калган авыл халкының табыш чыганагы булып нәрсә торыр?* Шәһри Казан

3) *икът.* Барлык керемнең аны алу өчен тотылган чыгымнардан арткан өлеше. *Һәр тиен табышны раслаган кәгазь булырга тиеш, налогларны вакытында түләргә, дигән фикергә килде.* Т.Галиуллин. *Узган елда алар 9– 10 катлы 20 йортка тәрәзә һәм ишекләр куеп, 5–6 миллиард сум саф табыш алды.* Шәһри Казан

4) Изүченең изелүче хезмәтеннән файдаланып тапкан кереме. --- *повесть мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылган, чөнки анда конфликт байлык, табышка омтылу, иҗтимагый мөнәсәбәтләр тирәсендә бармый, ә һөнәрсезлеккә, әхлаксызлыкка басым ясалып, каршылык мораль-әхлакый яссылыкта тудырылган.* Т.Гыйлаҗев

5) Эшләми генә табылган акча, бик җиңел кулга төшкән керем. *Аның шикелле азык-төлек кибетендә эшләүче сатучылар үз тамакларын гына түгел, туган-тумачаларын туендырып торалар, ә бу үзе өйдән ташып ашый һәм бер тиен табыш алып кайтмый иде.* В.Нуруллин. *Башкаланың Восстание урамында яшәүче 73 яшьлек ханымны: «Синдә бозым бар», – дип алдаучылар бик күп табыш күргән.* Безнең гәҗит

6) Умарта яки башка кортлар җыйган бал күләме. *Тигәнәк, сукыр кычыткан чәчәкләрендә кортлар гөҗли иде. Табыш бар дигән сүз.* А.Гыйләҗев. *Оя янына җайлабрак утырып, шөпшә китергән табышны пинцет белән җыеп барырга була.* Яшь натуралистларга

7) Ирешелгән уңыш. *Бигрәк тә сөюсәгадәт, тирән кичерешләр, табышлар һәм югалтулар турында җан ачысы белән язылган шигырьләр күңелне*

*айкап-айкап ала.* Ф.Яруллин. *Әйтик, анда шатлык белән кайгы, югалту белән табыш ---.* М.Кәбиров

8) Уйлап табылган нәрсә; ачыш, яңалык. *Кыскасы, сезнең режиссурада бер артист белән тапкан табышлар инде икенче артистка ярамый.* Ю.Сафиуллин. *Аның 1940–1950 нче елларда бу өлкәдәге эзләнүләре яңа табышка китерә.* Ф.Хәсәнова

◊ **Табыш артыннан куу** Беренче урынга матди мәнфәгатьләрне кую, мөмкин кадәр күбрәк табыш алырга омтылу. *Корпорацияләр, зур табыш артыннан куып, нефть экспортын даими рәвештә арттыра һәм ил эчендәге бәяне дә үзләре ничек тели шулай куя.* Ватаным Татарстан

**ТАБЫ́Ш ИТҮ** *ф.* Эшләп алу, табу, кулга төшерү. *Лимон сатып табыш иткән акчасын, көн дә ун тиенлек көмеш тәңкә биреп җибәрә-җибәрә, ул малайны яллап йөртте.* Ә.Фәйзи

**ТАБЫШ-КИҢӘШ** *җый. и.* Төрле киңәшләр; киңәш-табыш. *Юньләп, дөнья күргәнрәк кешеләр белән дә табыш-киңәш итеп кара әле.* Ф.Әмирхан

**ТАБЫШЛЫ** *с.* 1) Табыш китерә торган, табышы (*2–3 мәгъ.*) булган, төшемле. *Умартачылык исә элек-электән дәрәҗәле генә түгел, табышлы кәсеп саналган.* Л.Мәҗитова. *Хәсән үз кесәсенә зыянга эшли торганнардан түгел, аның һәр уе, һәр фигыле, һәр шөгыле табышлы.* К.Кәримов

2) Уңышлы, ундырышлы, мул. *Чәчәкләр баллы, һава кояшлы, Көне табышлы – Кортларым нигә Ачуланалар?* Ф.Бурнаш

**ТАБЫШМАК** *и.* **1.** 1) Төп мәгънәсен, җавабын уйлап табарга кирәк булган әйтем – фольклор әсәренең бер төре. *Халыкның рухи тамырлары гасыр тирәнлегендә, җимешләре риваять, әкият, мәкаль, табышмаклар булып безнең көннәргә килеп җиткән.* Ш.Галиев. *Йөзләгән табышмак арасында фәкать дүртесенең генә җавабы – ат.* Р.Харис

2) *күч.* Нинди дә булса серле, кыен аңлашыла торган нәрсә. *Ул бөтен барлыгы белән тоеп тора: әлеге фаҗигале табышмакны чишү өчен, Бәхтиярның кулында ачкыч бар.* М.Әмирханов. *Табышмак бу минем өчен, аңлаешлы гына итеп әйтә аласыңмы?* Э.Яһудин

**2.** *с. мәгъ.* Сәер, аңлашылмый торган. *Нәрсә әйтер икән, нинди серләрен ачар икән бу табышмак егет*? И.Салахов. *Улибаева – гомумән, табышмак кеше.* М.Мәһдиев. *Инде менә тагын бер табышмак сүз: универсиада диган хикмәтле лөгать йөрәкләрне җилкендерә.* Римзил Вәлиев

**ТАБЫШМАКЛЫ** *с.* 1) Табышмаклар, башваткычлар булган, шулар ярдәмендә барган. *Табышмаклы аңлашу исә гомумән борынгы дәверләрдә яшерен телнең актив кулланылуын чагылдыра.* Н.Хисамов

2) Серле, сәер; гаҗәп. *Шактый табышмаклы ике конвертны Рушад кесәсенә салып куйды.* М.Мәһдиев

**ТАБЫШСЫЗ** *рәв.* **1.** Табыштан башка, табыш булмыйча. *Салих Сәйдәшевтәге гаять көчле музыкаль табышларга бу текстның бернинди дә шигъри табышсыз, коп-коры язылуы һич тә тәңгәл килми.* Г.Рәхим. *Башка вакытта табышсыз булса да кайтып җитә иде, бүген юк та юк.* Г.Гыйльманов. *Байтак төбәкләрдә, табышсыз эшли дип, авыл кибетләре ябылды, район кулланучылар җәмгыятьләре таркалды.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* 1) Табышы булмаган. *Табышсыз аучы*

2) Табыш китерми торган. *Һәр район үзәгендә эшләп килгән китап кибетләре, табышсыз нокта буларак, юк ителде.* М.Кәбиров. *Балалар әдәбияты, балалар телевидениесенә бүген табышсыз өлкә дип акча салырга курыксак, безнең киләчәк нинди булачак?* Өмет

**ТАБЫШСЫЗЛЫК** *и.* Табыш булмау, керем китермәү күренеше. *Халиков Уфа губернасындагы авылларның бу өлкәдәге эшчәнлеген анализлап, XX йөз башына игенчелекнең бернинди дә үсешкә ирешмәвен, аның икътисади яктан табышсызлыгын тәнкыйтьли.* Л.Гобәйдуллин

**ТАБЫШТЫРУ** *ф.* Төрле җирдән эзләп, тырышып, нәтиҗәдә табу. *Мин генә ара-тирә кайткалап йөрдем. Әйтик, бала-чага белән, каяндыр бәләкәй сука табыштырып, бәрәңге утыртып килдем.* К.Миңлебаев. *Аларның орлыгын почта аша заказ белән кайтарттык, абыем Мәскәүдән дә табыштырды.* А.Сабирова

**Табыштырып тору** Гел табыштыру

**ТАБЫШУ** *ф. урт. юн.* 1) Табарга ярдәм итү. *Байбәтчә Йосыфҗан өчен яшерен паспортлар табышып бирергә Госманның вакыты табыла.* Г.Ибраһимов. *Ул атлар табышты, арбалар табышты, яралыларны больницага салырга ярдәм итеште.* И.Гази

2) Бер-берсен табу. *Табышалар, кочаклашалар, шатланышалар!* Н.Кәримова. *Гәрчә ул [Мәрфуга] Мәсагутьтән дүрт яшькә кечерәк булса да, бер урамда, чапырыш йортларда гына яшәгән ике йөрәк берсен-берсе бик тиз табыштылар.* В.Имамов

**Табышып бетү** Барысы да бер-берсен табу

**Табышып тору** Әле хәзер табышу; даими яки әледән-әле табышу

**ТАБЫШЧЫ** *и.* 1) Табыш эзләп йөрүче, табыш артыннан куучы. *Әмма моннан табышчылар да, салымчылар да байый гына, халык исә хәерчеләнә бара.* И.Әмирхан

2) Гаиләне асраучы, туйдыручы, акча табучы

**ТАВИС** *и. гар.* Фазан кошлар семьялыгыннан озын койрыклы, бик матур каурыйлы, Азиядә тереклек итүче эре кош; *русчасы*: **павлин**. *Тавис каурые белән матур, сандугач тавышы белән матур.* Мәкаль. *Ул түшендәге, сырт һәм канат тирәсендәге чуар каурыйлары җемелдәвен күрсәң – зоопарктагы тавис коштан бер дә ким түгел!* Р.Низамиев

◊ **Тавис канатыдай** Төрле төсләр кушылган, аллы-гөлле; артык чуар, җете төсле. *Гөнаһ шомлыгыдыр инде, теге егет белән очрашуга Мәгъфиянең тавис канатыдай төрле төсләр белән балкып торган күлмәген киеп чыгасым килде.* Ф.Баттал. **Тавис каурыйлары таккан карга** Үзен чынлыктагыдан әйбәтрәк, абруйлырак итеп күрсәтергә маташкан кешегә карата. *Зәйтүнә акылсыз кыз түгел, ул аның [Шәмгуньнең] тавис каурыйлары таккан карга икәненә төшенер.* Ә.Фәйзи. **Тавис**

**койрыгыдай** *к.* **тавис канатыдай**. *Түбәндә баягы таза чандыр егет, ялгызы гына әрҗәләр өеменә йөзе белән борылып, әлеге тавис койрыгыдай яулыгына карап тора иде.* Ә.Еники. **Тавис кошы кебек (сыман)** Күзгә бәреп торырлык, артык чуар, бик җете. --- *тавис кошы сымак киенгән орчыктай гына чегән кызы йөзек-беләзекләрен балкытып бии, әтисе гитара чиртеп, җыр көйли.* С.Шәрипов

**ТАВТОЛО́ГИК** *с. лингв.* Эчтәлеге белән бер үк фикерне кабатлаудан гыйбарәт, асылы тавтология булган (хөкем, гыйбарә тур.)

**ТАВТОЛО́ГИЯ** *и. гр. лингв.* Алда әйтелгән фикергә өстәмә ачыклык кертмичә, икенче сүзләр белән кабатлау; билгеләмә, дәлил бирелергә тиешле гыйбарәнең үзен дәлил буларак китерү күренеше. *Шулай итеп, «сарут үләне» дигән тәгъбирне бүгенге телебезчә таркатсак, «сары үлән үләне» дигән тавтология килеп чыга.* Г.Рәхим. *Тавтология булса да әйтим: Мохит абзаң «мохит» дигән төшенчәне аңлап җиткермидер, күрәсең.* Ә.Рәшит

**ТАВТОЛО́ГИЯЛЕ** *с.* Тавтологияләр кергән, тавтология моментлары булган (гыйбарә, сөйләм һ.б.ш. тур.)

**ТАВЫК** *и.* 1) Фазан кошлар семьялыгыннан бөтенләй диярлек оча алмый, йомыркасы һәм ите өчен асрала торган йорт кошы. *Тавык төшенә тары керә, ашамаса – тагы керә.* Әйтем. *Бер тавык көненә ничә йомырка сала?* М.Мәһдиев

2) Шул кошның ашарга яраклы ите. *Иптәшләрем сөйләвенчә, анда кыздырылган чиркәс тавыгы белән сыйлаганнар икән.* Г.Нәсин

3) Кайбер кошларның атамаларын белдергән кушма сүзләрнең бер компоненты. *Кайдадыр кор-р-кор-р килеп урман тавыгы көрелдәде, кичке саргылт күктә тилгән очып йөрде, якындагы агач башында пи-пи дип аның баласы кычкырды.* М.Мәһдиев

◊ **Тавык алачыгы** Бик кечкенә өй, бина турында. *Сугыштан соңгы кырык алтынчы ел булса кирәк, төгәл генә хәтерләмим, бер көнне безнең тавык алачыгы кадәр өебезгә авыл советы рәисе, районнан килгән берничә налук җыючы килеп керделәр.* Туганайлар. **Тавык аягы** *эвф.* 1) Христиан динендәге кешеләрнең муеннарына яки киемнәренә тага торган тәре; хач. *Кара тактаның эченнән «тавык аягы» да эзләп маташтылар.* Г.Тукай; 2) *иск.* Тәре формасындагы медаль. **Тавык баш** Бик аңгыра яки хәтере начар кешегә карата. *Син үзең тавык баш, уйлап кара, Кабан күле борын заманда бик зур булган.* А.Гадел. *Нәрсә аңладың син, тавык баш!* З.Хәким. **Тавык бәрәңгесе** Гадәттә сайлаган вакытта кош-корт, хайван азыгына дип аерып куела, пешергәндә, кабыгы белән пешерелә торган вак бәрәңге. *Ә күп очракта өстәлдә каткан икмәк сыныгы белән тавык бәрәңгесеннән артык берни булмый.* К.Кара. **Тавык бете** Үтә вакчыл кеше. **Тавык йөрәк** Куркак һәм ышанычсыз кеше турында. *Андый батыр малайлар безнең очта бармы соң? Җыен куркак, җыен тавык йөрәк.* Г.Бәширов. **Тавык кетәге** *к.* **тавык алачыгы**. *Дөрес, Хәтмулла абзыйның үзенең дә өе тавык кетәге зурлыгында гына.* С.Поварисов. **Тавыклар белән (бергә) яту** Йокларга элек кичтән, караңгы төшәр-төшмәс яту. *Безнең шулайрак инде: тавыклар белән ятабыз, беренче әтәчләр белән торабыз...* М.Хәсәнов. **Тавыклар көләр** Беркатлы һәм урынлы-урынсыз сүз һ.б. турында. *Яраткандыр дисәң, тавык көләр, нинди ярату, әллә ул күз явын алырлык чибәрме?* К.Кара. **Тавык мие ашаган** *к.* **тавык мие эчкән**. *Атаң бирмәгән акылны бирәләр, тавык мие ашамаган булсаң, сөйләгәнгә колак сал!* Т.Гыйззәт. *Аңгыра, томана, чүпрәк баш, тавык мие ашаган нәмәрсә!* Р.Батулла. **Тавык мие капкан** *к.* **тавык мие эчкән**. *Итәгенә ут капканчы гыр-гыр йоклар да, итәге яна башлагач чыгып чабар, тавык мие капкан нәрсә!* В.Нуруллин. **Тавык мие эчкән** Начар хәтерле, зиһенсез кеше турында. *Алтын тутырылган сандыкны чоланга чыгарып куярга син аны тавык мие эчкән дип белдеңме әллә?* А.Гыймадиев. **Тавык оясы кадәр** *к.* **тавык алачыгы кадәр**. **Тавык тәпие** *к.* **тавык аягы**. *Син, егет, бик масайма әле! Шинелеңә --- тавык тәпие кадап кайткач та, үзеңне становой дип белдеңме?* К.Нәҗми. *Гүя көннәрең санаулы гына калды, басурман, тиздән муеныңа тавык тәпие тагачаклар, дип әйтергә тели иде.* М.Әмирханов. *Үзе Юлдашны чукындырып алды һәм сандыктан тавык тәпие – тәре тартып чыгарды.* Т.Нәбиуллин. **Тавык чүпләп бетергесез (бетерерлек түгел, бетермәслек)** Бик күп вак эш, борчу, мәшәкать һ.б.ш.лар турында. *Ә авыл укытучысының эше тавык та чүпләп бетерерлек түгел.* Ә.Хәсәнов. *Сораулар, хәл итәсе мәсьәләләр тавык чүпләп бетермәслек булып чыкты.* А.Гыймадиев

**ТАВЫ́К ЕЛЫ** *и.* Аерым хайван исемнәре буенча төзелгән борынгы еллар йолдызнамәсендә унынчы ел. *Тавык елы. Кәбисә елы артындагы беренче ел.* К.Насыйри

**ТАВЫККҮЗ** *и. бот. диал.* Бөрлегән

**ТАВЫ́К КҮЗЕ** I *и. мед.* Башлыча, организмга А витамины җитмәү сәбәпле, эңгер-меңгердә һәм сүрән яктылыкта начар күрүдән гыйбарәт күз авыруы. *[Сабир:] Кысыр аш белән генә торалар, дип ишеттем. Тавык күзе булмасын, дип кызганам.* Т.Гыйззәт

**ТАВЫ́К КҮЗЕ** II *и. бот. к.* **тавык үләне**

**ТАВЫ́КСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Яңа аңкаулыларның башлыча очмый торган, тибенергә һәм йөгерергә яраклашкан нык аяклы биш семьялык кошларын берләштергән, бик киң таралган отряды

**ТАВЫ́К ТАРЫСЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан башаклары берьяклы себеркәч хасил итә, су буйларында, сазлыкларда үсә торган үлән; керпе үләне; *русчасы:* **ежовник**

**ТАВЫ́К ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан сазламык җирләрдә, су буйларында үсә торган, түгәрәк яфраклы, алтын сары чәчәкле агулы үлән үсемлек; *русчасы*: **калужница**. *Чыкса – чикерткәле, чыклы, тавык үләне исле бер гаҗәеп төн иде.* М.Мәһдиев

**ТАВЫ́КЧАЛАР** *и. зоол. күпл.* Тавыклар һәм шуларга якын кардәш кошлар керә торган семьялык

**ТАВЫК-ЧЕБЕШ** *җый. и.* Тавыклар һ.б.ш. вак кош-корт. *Ә ул үзе яшел чирәмле ишегалдында тавык-чебеш ашатып йөри, имеш.* Ә.Гаффар. *Терлеген бетергән очракта да, тавык-чебешен үстерүен дәвам итә авыл халкы.* Татарстан яшьләре

**ТАВЫК-ЧЕБИ** *җый. и. к.* **тавык-чебеш**. *Мал-туар, тавык-чеби, мунча – барысы да килгән кунакларның кәефен күтәрү өчен эшләнә.* Ватаным Татарстан. *Ял итеп туймаган гәүдәңне кузгатып, иртүк торырга, тавык-чеби, казүрдәкләреңне ашатып, алар өчен бәрәңге пешерергә куярга.* Татарстан яшьләре

**ТАВЫШ** *и.* 1) *физ.* Мохиттә материаль кисәкчекләрнең тирбәнеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм ишетү әгъзалары кабул итә торган дулкыннар. *Тавыш чыганагы. Тавыш дулкыны. Тавыш тизлеге*

2) Бугаздагы махсус ярылар тирбәнүдән чыга торган һәм шәхсән үзенчәлекләр – көч, югарылык-түбәнлек, тембр һ.б.ш.лар белән аерылып торган авазлар. *Әмма ул җавап бирергә өлгергәнче, караңгыдан Ләйсәннең яңгыравыклы тавышы ишетелде ---.* А.Гыймадиев. *Матур гына тембрлы хатын-кыз тавышы динамиклар аша яңгырый ---.* А.Гадел

3) Җырлаганда, тавыш ярыларының яңгырау үзенчәлеге, яңгырау сыйфаты; җырлау сәләте. *Нинди эш инде бу: сәхнә тулы йолдыз, үзләренең берсенең дә тавышы юк.* Р.Миңнуллин. *Классик тавышлар сагындырды. Яңа дәвер ачыла. Сәхнәгә консерваториядә белем алган җырчылар килә. Бу – зур шатлык.* Ш.Баһаутдин

4) *муз.* Вокаль яки инструменталь әсәрдә аерым мөстәкыйль партия. *«В землянке», «Огонёк», «Тёмная ночь», «Моя любимая», «Вечер на рейде», «В лесу прифронтовом» кебек җырларны дүрт тавышка яңгыратабыз.* М.Мәһдиев

5) *муз.* Музыкада яки җырда яңгыраган аерым аваз; нота. *Музыкада да төп тавышлар җидәү: до, ре, ми, фа, соль, ля, си.* М.Мәһдиев

6) Уен коралының яңгырашы. *Күз карасыдай кадерле, ягымлы, тылсымлы тавышлар чыгарырга сәләтле гармунны ялкын өстенә китергәндә, малай чытырдатып күзләрен йомды.* Н.Әхмәдиев

7) Берәр табигать күренеше, хәрәкәт барышында, җайланмаларның эшләве вакытында чыккан авазлар. *Шулчак якында гына чырт-чырт итеп коры куак чыбыклары сынган тавыш ишетелде.* А.Хәсәнов. *Аннан нindидер механизм эшләгәндәге кебек шыгырдаган тавыш ишетелә.* А.Тимергалин. *Кинәт бакча караңгылана төшә, каты җил искән тавыш, күк күкрәве, яшен яшьнәве яшьләрне шомландыра ---.* А.Гадел

8) Хайваннар һәм кошлар чыгарган авазлар. *Тирә-юнь сандугач тавышларына күмелде.* Р.Сәгъди. *Күптән ишеткәне юк иде аның бүре тавышын да.* Т.Гарипова

9) Шау-шу, ыгы-зыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән авазлар, гөрелте. *Әле генә тавыш, шау-шу белән тулы мәйдан өстен Күчем, Уразай, Туйкә батырларның --- әмерләре күмеп китте.* В.Имамов

10) *кино* Фильмның визуаль өлеше белән беррәттән барган сөйләшү, музыка һ.б.ш.лардан торган өлеше

11) Бәхәс, ызгыш, гауга, җәнҗал. *Күрше тавыгы түгел, алмагачка ят чыпчыклар килеп кунса да, шундук тавыш куптара.* А.Хәсәнов. *Ә салдымы – тавыш чыгара, әнигә бәйләнә, бер дә юкка аны кимсетә башлый.* В.Нуруллин

12) Дәүләт һәм иҗтимагый оешмаларда төрле мәсьәләләр хәл ителгәндә, үз фикереңне белдерү хокукы; әлеге белдерелгән фикер үзе. *Һәркемнең үз эше тавышка куелды. Бер тавышка өстенлек белән яшьләр кабул ителде.* Ә.Баян. *Шулар [вәкилләр] арасында иң күп тавыш алган кеше Г.Ибраһимов булды.* Ә.Бикмурзин

13) **тавышлар** *сөйл.* СССР чорында капиталистик илләрнең советка каршы пропаганда алып барган радиостанцияләре

14) **тавышлар** *сөйл.* Кайбер психик авыруларда була торган, чынлыкта булмаган авазлар ишетүдән гыйбарәт галлюцинация төре. *Тән сызлавы бетте, ләкин җан әрнүе әле дә бар, көн саен нindидер тавышлар ишетелә, нindидер исләр килә, баш өстеннән очкычлар очып үтә.* А.Гыйльми

◊ **Тавыш адашырлык** Иркен, зур (бүлмә, бина тур.). *[Әзһәр] Хатамтаевлар квартирасының зурлыгына хәйран булды. Кем әйтмешли, тавыш адашырлык.* Б.Камалов. **Тавыш бирү** 1) Дәшү, тамак кыру яки башкача үзеңнең барлыгыңны, кайдалыгыңны белдерү. *Бәхтиярне югалттылар. Фатыйма күпме генә чакырмасын, тавыш бирмәде.* З.Кадыйрова; 2) Кычкырту, сигнал, гудок бирү. – *Сезне капка ачып каршылыйлар, кычкыртып тавыш биримме? – диде таксист.* З.Кадыйрова. *Табын әзерләп, өстәл тирәли утыруыбыз булды, ишек кыңгыравы тавыш бирде.* Шәһри Казан; 3) Сайлаулар, җыелыш һ.б.ш.ларда катнашып, үз фикереңне рәсми рәвештә белдерү. *Акция үзенең иясенә акционерлар җәмгыятеннән дивидендлар, ягъни табыш алырга, акционерлар җәмгыятенең җыелышларында тавыш бирергә мөмкинлек ача.* Татарстан яшьләре; 4) Кая да булса бару теләге белән юлдагы очраклы машиналарга кул күтәрү. *Мин барасы районга киткән автобусларның күптән инде эзе суынган. Нишләргә? Әлбәттә, җиде юл чатына басарга да узган машинага кул күтәреп тавыш бирергә.* Р.Гатауллин. **Тавышка кую** Билгеле мәсьәләгә карата рәсми рәвештә фикер белдерергә тәкъдим итү. *Аннары Гадел абый мәсьәләне тавышка куйды.* В.Нуруллин. *Ике тәкъдимне дә тавышка куйдылар.* Г.Галиева. **Тавышка килү** Берәр кеше белән әрләшү, кычкырышу, ачуланышу. *Әйе, үзгәрде Александр Иванович, ни кылганын үзе дә аңлап бетермәде, акылын нидер томалады: улы белән тавышка килеп, чит илгә үк чыгып китте.* З.Кадыйрова. *Рафис белән Талия, юкка гына тавышка килгән җирдән, бер-берсенә баш иясе килмичә, горур гына икесе ике юлдан китеп баралар.* Татарстан яшьләре. **Тавыш кубару** Гауга чыгару, тавышлану. *Аш сыек дип, иң элек син тавыш кубара идең.* Х.Камалов. *Тавыш кубармый гына аңлатуга ни җитә.* Ф.Дәүләтбаев. **Тавыш кубу** Ыгы-зыгы, чыр-чу барлыкка килү;

гауга чыгу. *Кабинетта тагын коточкыч тавыш куба, мондыйны аның әле бер генә бюро утырышында да күргәне юк иде.* Р.Мирхәйдәров. **Тавыш күтәрү** 1) Тавышлану, тавыш чыгару, гауга куптару. *[Хуҗа:] Соң шулай булгач? Өч сум өчен минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы?* Мәзәк; 2) Берәүне кычкырып сүгү, җикеренү. *Кадрия санэпидстанциядәге бөтен кешене эттән алып эткә сала, ә Җәмилгә менә тавыш күтәрә алмый.* В.Имамов. **Тавышны бөердән алу** *к.* **тавышы бөереннән чыгу**. *[Бариев] үзеннән түбәнрәкләр янында тавышын бөердән алып сөйләшә.* Б.Камалов. **Тавышы бөереннән чыгу** Үзенә ышанып, курыкмыйча, тартынмыйча, көчле тавыш белән сөйләшү турында. *Баштарак бик мескенләнеп, ух-ах килеп йөрсә дә, соңга табарак тавышы бөереннән чыга башлады моның [Шакирның].* Р.Төхфәтуллин. *Бизәнеп-ясанып кына йөри, тавышы бөереннән чыга, нидер эшлим дип иелмәс тә, бөгелмәс тә үзе.* Татарстан яшьләре. **Тавышы киселү** Кинәт тавышы бетү; тавыш өзелү, тынып калу. *Хисмәт абзыйның калтыравыклы тавышы киселде.* Р.Гали. **Тавышы таш яру** Бик көчле, яңгыравык тавыш турында. *«Катюша»ның тавышы таш ярырдай көчле генә түгел, моңлы да икән.* С.Поварисов

**ТАВЫ́ШАЛГЫЧ** *и. тех.* Төрле, гадәттә су астында булган тавыш һәм ультратавышны кабул итә торган аппарат; гидрофон

**ТАВЫШ-ГАУГА** *җый. и.* Талаш, ызгыш, кычкырыш. *Ул йомшак күңелле, кешелекле иде, тавыш-гауга яратмый...* Л.Шагыйрьҗан. *Билгеле, монда әйбер булу, канәгатьсезлек нигезендә төрле тавыш-гауга да килеп чыгарга мөмкин.* Л.Гобәйдуллина

**ТАВЫ́ШЙОТКЫЧ** *и. тех.* **1.** 1) Тавыш дулкыннарын тотып калу өчен махсус киртә, катлау, өслек; тавыш изоляциясе; *русчасы:* **звукопоглотитель**. *Бетоннар еш кына махсус материаллар (җылысаклагыч, тавышйоткыч, гидроизоляция һ.б.) белән бергә кулланыла.* Төзү материаллары

2) Эшләп торган механизм, двигатель һ.б.ш.ларның тавышын киметү җайланмасы; *русчасы:* **глушитель**

3) Шартлау тавышын йоту өчен утлы коралның көпшәсенә беркетелә торган җайланма; *русчасы:* **глушитель**. *Тикшерү барышында күп кенә корал табылган: 31 пистолет, 9 тавышйоткыч, 9 көпшәсе киселгән мылтык, 7 автомат һ.б.*

**2.** *с. мәгъ.* Тавыш дулкыннарын йота, үзеннән ары уздырмый һәм кире яңгыратмый торган. *Гравий чыгару районы начальнигының эш кабинеты пароходның койрык ягында ике каютаны бер итеп зурайтылган, түшәм һәм стеналары тавышйоткыч зәңгәрсу тукыма белән каплаулы иркен бүлмәдә урнашкан.* С.Сабиров. --- *[завод] минераль мамыктан түбә, фасад, идән һәм япсарларны җылыту өчен материаллар, шулай ук утка чыдам һәм тавышйоткыч плитәләр җитештерәчәк.* Фән һәм тел

**ТАВЫШКАН** *и. зоол.* 1) Дала, ярымчүл һәм чүл зоналарында таралган, чагыштырмача кыска гәүдәле һәм озын, көчле арт аяклы кимерүче җәнлек; кушаяк; *русчасы:* **тушканчик**

2) *иск.* Куян. *Кайбер галимнәр төрки телләрдәге хайван исемнәрендәге -ан элементын (чагыштыр: арыслан, каплан, сыртлан, кабан, колан, болан, елан, чаян, җаян (хәзерге җән), сазан, табан, йомран, сычкан, тавышкан, көзән, чытан һ.б.) аң, ау – «киек» сүзеннән дип хисаплыйлар ---.* Р.Әхмәтьянов

**ТАВЫШКАН ЕЛЫ** *и.* Һәр елы аерым хайван исеме белән аталган борынгы уникееллык циклда дүртенче ел, куян елы

**ТАВЫШЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тавышлану** (*1 мәгъ.*). *Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер. Аллаһ юлында сугыш өчен сулуларын тавышландырып чабучы атлар илә ант итәм.* Ногмани

2) *махс.* Тавышлы итү, төшерелгән теле-, видео- һ.б.ш. фильмнарга тавышлар, авазлар, музыка өлешен өстәү, тавыш яздыру. *Аны [сериалны] тәрҗемә итү һәм рольләргә бүлеп тавышландыру белән шөгыльләнүче – «Дубль-видео» студиясе.* Сәхнә

**Тавышландыра башлау** Тавышландырырга тотыну

**Тавышландырып бетерү** Тулысынча тавышландыру

**Тавышландырып кую** Тавышландырып әзер хәлгә китерү

**Тавышландырып тору** Даими яки әледән-әле тавышландыру; әле, хәзерге вакытта тавышландыру

**ТАВЫШЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Берәр төрле аваз, тавыш, өн чыгару. *– Акрын... Тавышланма инде... – Мәхмүт үрелеп Генаның күлмәгеннән тартты, – дежурныйны китерерсең.* И.Салахов. *Бер уңайда соңга калган кайсыдыр колхозның чабу машинасы тавышлана.* Г.Бәширов

2) Ыгы-зыгы, шау-шу куптару. *Читтән карасаң, мөгаен, исең китәр иде: барысының да чәчләре җиткән, сакаллары үскән, йөзләре агарган, үзләре акылдан шашкан төсле тавышланалар, коридорның әле бер, әле икенче ягына чабалар, егылалар, кочаклашалар.* И.Салахов

3) Гауга чыгару, җикеренү (бер кеше тур.). *Кайтырга чыккан халык арасында, тау битендә, Миңнулла тавышлана иде.* М.Мәһдиев. *Эчкәч исә гадәте начар: юк-бар сүз белән Фәрзанәсенең җанын ашый, эт итеп сүгә, тавышлана, җикеренә.* Ә.Сафиуллин

4) Үзара ызгышу, талашу (күп кеше тур.). *[Мәтрүшкә:] Тынычланыгыз әле, балалар. Тавышланып кына берни дә хәл итеп булмый.* Ш.Фәрхетдин. --- *бер акыллысы шәп киңәш бирде: – Сез юк өчен баш ватмагыз: күршеләр тавышлана дип кенә, кеше йорт ташлый димени!* Р.Хәкимов

5) Бик көчле авазлар, тавышлар чыгару (җансыз нәрсәләр тур.). *Җилдавылның җенләнеп тавышлануын тыңлый-тыңлый оеп китте.* Г.Ибраһимов. *Учакның ялкыны тавышланып, сызгырып, гөжләп югары үрли-үрли яна башлады.* Р.Гариф

**2. тавышланып** *рәв. мәгъ.* Тавышлы итеп, тавыш белән, тавыш чыгарып. *Мин тавышланып еларга тотындым.* Г.Исхакый. – *Уф Алла, – Гений тавышланып көрсенде, – Зифа... Зифа җанкисәгем җырлый бит.* И.Салахов

**Тавышлана бару** Тавыш ныграк чыгару, ыгы-зыгы, шау-шуны акрынлап арттыру

**Тавышлана башлау** Тавышланырга тотыну. --- *[хуҗа белән хуҗабикә] бик нык талашып киттеләр. Аннары һәр кичне бер дә юктан гына тавышлана башладылар.* А.Хәсәнов. --- *бөтенләй үзгә юлга чыгып, шәһәрне артта калдыра башлагач кына, Зөлфия пошынып, шомланып, тавышлана башлады: – Кая алып барасыз мине?* Т.Галиуллин

**Тавышлана бирү** Бернигә карамый тавышлану

**Тавышлана тору** Әлегә тавышлану; күпмедер вакыт тавышлану. *Ниһаять, күп тавышлана торгач, люк ачылды, немецлар, кулларын күтәреп, танктан чыктылар, шунда ук аларны урап та алдылар.* Х.Камалов

**Тавышлана төшү** Тавышны, шаушуны арттыру

**Тавышланып алу** Аз гына вакытка тавышлану. *Кайдадыр шыгырдап капка ачыла, каз-үрдәк тавышланып ала.* М.Мәһдиев. --- *кешегә ачык, ярдәмчел, кунакчыл, баскан җирендә ташны изгән, тимерне өзгән, җәмәгате белән еш кына тавышланып алырга яраткан Лотфулланы халык «Зимагур» дип атый.* А.Хәлим

**Тавышланып бетү** Тәмам, бик нык тавышлану. *Күрше ире белән тавышланып, сугышып бетте, хөкем алдына басты.* Кызыл таң

**Тавышланып йөрү** Һәр җирдә, һәрвакыт тавышлану. *Көнләште, юкбар гаеп такты. Анысы гына җитмәгән, эшләгән урынга барып әләкләшеп йөрде, тавышланып йөрде ---.* Н.Фәттах. *Сылу каеннарның бөдрә чәчен туздырып ала һәм бер сәбәпсез тавышланып йөрүеннән оялган сыман тынып кала.* А.Мансуров

**Тавышланып карау** Тавышланырга маташу. *Урамда болыт куеру белән, аның [әбисенең] башы авыртырга гына тора. Андый чакта тавышланып кара.* Д.Бүләков

**Тавышланып кую** Берара тавышланып алу; аз гына тавышлану. *Төнге таллыкта ялгыз кош саташып тавышланып куя.* Р.Бәшәр

**Тавышланып тору** Даими яки әледән-әле тавышлану; әле, хәзерге вакытта тавышлану

**Тавышланып утыру** *сөйл. к.* **тавышланып тору**. *Әйдә, үлгән хатын өчен тавышланып утырмыйк.* Н.Әхмәдиев

**Тавышланып чыгу** Билгеле вакыт аралыгын берөзлексез, туктаусыз тавышланып үткәрү. *Ул төне буе тавышланып чыкты*

**Тавышланып яту** *сөйл. к.* **тавышланып тору**. *Эшегез юк, шуңа тавышланып ятасыз.* Н.Көбәш

**ТАВЫШЛА́У** *ф.* 1) Берәр эшхәрәкәтне башкарганда, төрле авазлар чыгару, гомумән тавыш барлыкка китерү. *Урман элеккечә шаулый, тавышлый.* С.Хәким. *Алар инде нык кына салганнар, хәтта исерә төшкәннәр һәм шактый тавышлап сөйләшә башлаганнар иде.* М.Хәбибуллин

2) *сөйл.* Ыгы-зыгы чыгару, шау-шу куптару. *Тиз кит, малай, өй түрендә тавышлама.* Г.Тукай. *Акрын! Бу – мин, нигә тавышлыйсың? Кеше ишетер, тавышың чыгарма.* Ф.Бурнаш. *Ул ишекне япмыйча ук тавышлый-тавышлый китеп барды.* Ш.Камал

3) *сөйл.* Сүгенү, җикеренү; талашу, ызгышу. *Анда бик күп егетләр, чәчләрен алдырырга кызганып, тавышлап маташалар.* Һ.Такташ

**Тавышлап алу** Аз гына, берникадәр вакыт кына тавышлау

**Тавышлап китү** Билгеле моменттан алып яки кинәттән тавышлау

**Тавышлап тору** Даими, берөзлексез тавышлау; әле, хәзерге вакытта тавышлау. *Зыянның иң элек дикъкатен алган нәрсә: зур мәйданга җыелган халыкның шул дәрәҗәдә күплеге һәм аның, сарылы, аклы вә каралы төстә булып, бертуктаусыз селкенеп, бер яктан бер якка чайкалып һәм тавышлап торуы булды.* Г.Ибраһимов. *Үтәли җил эчендә уйнап, сузып тавышлап торган...* Н.Абдулкәримова

**Тавышлап яту** *сөйл. к.* **тавышлап тору**

**Тавышлый башлау** Тавышларга тотыну

**Тавышлый бирү** Бернигә карамый тавышлау

**Тавышлый тору** Әлегә тавышлау; әледән-әле тавышлау

**ТАВЫШЛЫ** *с.* 1) Билгеле тавышы булган, билгеле тавышка ия. *Тоныграк, куе, йомшак тавышлы альт – думбра телгә килә.* Д.Каюмова. *Ә яңа укытучы гөлдерәвек тавышлы, зифа буйлы, чибәр генә, яшь кенә кыз иде.* М.Шаһимәрдәнов

2) Тавыш ярдәмендә белдерелә торган. *Алар машиналарының утлы, тавышлы сигналларын үз куллары белән алып куйганнар, имеш.* Татарстан яшьләре

3) Тавыш белән тәэсир итә торган. *Эчке эшләр идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, фанатлар җыелган урында яктырткыч тавышлы граната, --- телескопик металл күсәкләр һәм башка шундый кораллар табылган булган.* Безнең гәҗит

4) Шау-шулы, гөрелтеле, ыгы-зыгылы. *Мәскәү – колачлап булмаслык зур, тавышлы, ыгы-зыгылы кала.* Татарстан яшьләре. *Гомер буе Казанда заводта, тавышлы цехларның берсендә эшләгән һәм шуннан чукрак калган.* Безнең гәҗит

5) *кино* Визуаль өлеше белән беррәттән сөйләшү, музыка һ.б.ш.лар да булган, тавыш яздырылган. *Бозык сурәтле яисә бозык тавышлы эшләрнең күчермәләре конкурста катнашмый.* Татарстан яшьләре. *Тавышлы кино*

6) Күп сөйләүчән; артык кычкырып сөйләшүчән; шау-шу чыгаручан. *Ставропольдә бер тәрбияче «артык тавышлы» алты яшьлек кызчыкның авызына скотч ябыштырып куйган.* Татарстан яшьләре

7) *күч.* Гаугалы, җәнҗаллы. *Тавышлы йортта бәрәкәт булмас.* Мәкаль. *Тавышлы табыннан фәрештә качар.* Мәкаль. *Коридор тулы буш шешәләр, димәк, мондагылар күп эчә. Димәк, тавышлы тормыш булачак икән.* Р.Гаязетдин

8) *күч.* Бәхәсле, дәгъва белдерелгән. *Хәзер тавышлы фатирны сатачаклар да суд чыгымнарын --- чигергәннән соң калган акчаны диджейның кулына тоттырып: «Дүрт ягың кыйбла!» – дип әйтәчәкләр.* Татарстан яшьләре

**ТАВЫШЛЫ́-ТАВЫШСЫЗ** *с.* Җырлау сәләте төрле дәрәҗәдә булган. *Бүгенге үзен йолдыз дип санаган*

*тавышлы-тавышсыз яшьләрдән ул күпкә уздыра бит, уздыра!* Кәеф ничек?

**ТАВЫШ-ӨН** *җый. и. к.* **тавыш-тын**. *Сөйләм дибез икән, димәк, монда телдән башка әле шагыйрьнең тавыш-өн, ым-ишарәләре, фикерне, хисне белдерә торган бүтән чаралары да искә алынырга тиеш.* Мәдәни җомга

**ТАВЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Гомуми тынлык булган, бернинди тавыш (*1 мәгъ.*) булмаган. --- *һәм гомер буе үзеңне мәңгегә чорнап алган тавышсыз дөнья.* Ф.Бәйрәмова

2) Тавышы (*2 мәгъ.*) булмаган, сөйләшә алмаган. *Кешене тәмәке тартудан биздерү өчен, онкология хастаханәсенең лор бүлегенә кереп чыгу да җитә. Бугазлары тишекле, тавышсыз кешеләрне күрү яман гадәтне оныттыру өчен бик җитә.* Сәхнә

3) Тавышы (*3 мәгъ.*), җырлау сәләте булмаган. *Соңгы елларда сәхнәне, бигрәк тә эстраданы, тавышсыз, зәвыксыз җырчылар басып китте.* Р.Вәлиев. --- *филармониядә эстрада бүлеге, ягъни җыр сәнгатен үз тирәсенә туплап, тотып торучы үзәк таркалмаган булса, бәлки, җыр сәнгате бүгенге көндә бу хәлгә төшмәс, көйсез җырлар, сүзсез шигырьләр, тавышсыз җырчылар өстенлек алмас иде...* Казан утлары

4) Бернинди аваз, тавыш (*7 мәгъ.*) чыгармый торган. *Айсылу кире борылып, җитез һәм тавышсыз адымнар белән клуб ягына таба китте.* Г.Бәширов. *Бу – һәлак булган геройларга соңгы, тавышсыз салют иде.* Г.Әпсәләмов

5) Сүз белән әйтелмәгән, телдән яңгыратылмаган. *Шулай да мондый хәл тавышсыз протестка якын иде.* М.Хуҗин. *Кинәт барысы да тынды, ниндидер тавышсыз боерыкка буйсынгандай бер якка карап сүзсез калдылар.* Ф.Латыйфи

6) Гөрелтесез, шау-шусыз. *Җәелгән ямь-яшел кырлар, болыннар; Тавышсыз, тынсыз, аулак һәр урыннар.* Г.Тукай

7) *кино* Тавыш (*10 мәгъ.*) яздырылмаган яки гомумән шунсыз төшерелгән. *Кинотеатрларда тавышсыз фильмнар да күрсәтәләр.* Ф.Мөслимова. *Шул көнне абыйлар мине тавышсыз кино карарга алып барды.* Татарстан яшьләре

8) Сигнал бирү, музыка уйнату һ.б.ш. функциясе булмаган, бозылган яки сүндереп куелган (радио, телевизор һ.б.ш. тур.). *Мәчеткә кергәндә исә [телефонны] бөтенләй сүндерергә яисә тавышсыз режимга куярга кирәк.* Яңарыш. *Тавышсыз телевизор*

9) Ыгы-зыгысыз, тыныч. *Парк – шәһәрнең иң тавышсыз почмагы*

10) Бәхәссез, гаугасыз, ызгыш-талашсыз

11) Аз сүзле, сүзгә саран; буш сүз сөйләү һәм мактану гадәте булмаган. *Шашлыкны ашап бетерүгә, тавышсыз картка ияреп, яшь кенә бер кыз килеп керде, кул юарга кечкенә ләгән урнаштырды, комганнан су салып торды, дәстәрханны җыештырды, савыт-сабаны алыштырды, газетлар кертте.* Р.Мирхәйдәров

12) *күч.* Күндәм, сабыр, карусыз, юаш. *Бар басынкы, тавышсыз, гаугасыз, сабыр кешеләр, бер баксаң, алар йомшак, сыек буынлы булып күренә, әмма чынлыкта бу кешеләр үзсүзле, башлаган эшне ташламас, хатын-гаилә белән уйнамас, хыялга гына таянып, вакытны бушка әйләндермәс ---.* Р.Батулла. *Клёпа да элеккеге тавышсыз, җебегән һәм ялкау Клёпа түгел хәзер, ир-егетләр кыяфәте кергән.* С.Шәрипов

13) Үз фикерен әйтә алмаган, фикер әйтү хокукы, мөмкинлеге булмаган. *Делегатлар монда тавышсыз статистлар гына иде.* Р.Зәйдулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бернинди тавыш, аваз чыгармыйча. *Агыйделкәйләрнең ярларыннан Агадыр ла сулар тавышсыз; Бар микән соң җирнең күкрәгендә Яшәүчеләр моңсыз, сагышсыз?* Җыр. *Калын имән такталар тавышсыз ачылды, төсле пыялалар аша саркыган сүрән яктылыкта ул әлеге дә баягы кара киемле кешене күреп алды.* Ф.Латыйфи

2) Тавышы (*2 мәгъ.*) булмыйча, сөйләшү сәләтен югалтып. *Операциядән соң, Сабантуйда көрәшчеләргә көч бирәм дип кычкыра торгач, тавышсыз йөрдем бит бер ай.* Н.Кәримова. *Күкрәгем белән бик каты бәрелдем. Күпмедер вакыт тавышсыз йөрдем.* Кәеф ничек?

3) Дәшмичә, сөйләшмичә. *Шәүкәт үзенең шул урынында иде. Ул гаҗәп бер рәвештә кабер читенә таянган, тавышсыз утыра иде.* Г.Тукай. *Фёдоров, күз яшьләренә буылып, тавышсыз гына хатынының үле гәүдәсе янында миңгерәүләнеп утырды.* А.Расих

4) Тавышы (*3 мәгъ.*) булмый торып, җырлау сәләте булмаган көе. *Бернинди көе булмаган җырларны бернинди тавышсыз җырлый алалар бит.* Р.Миңнуллин

5) Сигнал бирү, музыка уйнату һ.б.ш. функциясе булмыйча, бозылган яки сүндереп куелган килеш (радио, телевизор һ.б.ш. тур.). --- *менә бер вакыт тапшыру тавышсыз бара, ә берничә минуттан алабугалылар бу хакта шылтырата да башлый.* Алабуга нуры

6) Ыгы-зыгы тудырмыйча, шау-шу куптармыйча. *Урыс булсалар да Ходай бәндәләре бит. Берсе дә кеше үтерергә атлыгып тормый. Тавышсыз гына ике якка аерылып, тар гына коридор хасил итәләр.* З.Зәйнуллин

7) Тату булып, тыныч рәвештә. *Регламент буенча әкрен генә, тавышсыз гына эшлик.* Т.Миңнуллин. *Бер гаиләдә өч буын вәкиле тавышсыз, матур, үрнәк гаилә булып гомер итә.* Туган як

8) Бәхәссез, ризасызлык белдермичә, ызгыш-талаш чыгармыйча. *Һәм аннан соң 309 нчы законны кабул иттеләр, бары урыс телендә генә имтиханнар тапшырырга, диделәр – анысы да тып-тын, тавышсыз үтте, Татарстан хуҗалары да, халык та ризасызлык белдермәде.* Безнең гәҗит. *Җыен каршылыкларсыз, үпкәсез, тавышсыз үтте.* Дуслык

**ТАВЫШСЫ́З-ӨНСЕЗ** *с. к.* **тавыш-тынсыз**. *Аны тау башына кадәр, тавышсыз-өнсез төнге сакчылардай, юл читендәге тәбәнәк баганалар озата менде, аның ара-тирә ишетелеп киткән аяк тавышларын юл өстенә җәенке башларын иеп утырган карт өянкеләр тыңлап калдылар.* Г.Бәширов. *Җан-рухыннан мәхрүм калган кеше кебек, тавышсыз-өнсез генә өйгә керде дә, башын күтәреп тә карамыйча, мыштым гына өстәл артына барып утырды.* Г.Гыйльманов

**ТАВЫШСЫ́З-ТЫНСЫЗ** *с. к.* **тавыш-тынсыз**. *Маңгаен ак яулык белән*

*кысып бәйләр иде дә һич бетәсе булмаган өй эшләрен тавышсыз-тынсыз гына эшләп йөрер иде*. Л.Ихсанова. *Гәүдәсе аюныкы кадәр булса да, тавышсыз-тынсыз йөри белә иде Гайфулла.* Ф.Яруллин

**ТАВЫ́ШТОТКЫЧ** *с.* **1.** *и. тех.* Ерактан килгән бик акрын авазларны кеше ишетерлек итеп көчәйтә торган аппарат

**2.** *с. мәгъ.* Тавышны ерактан билгели һәм көчәйтә торган

**ТАВЫШ-ТЫН** *и.* 1) Нинди дә булса тавыш, аваз. *Кайдадыр, тынып калган авыл өстендә, бик ялкауланып, теләр-теләмәс кенә этләр өрүеннән башка тавыш-тын юк иде*. М.Хәсәнов. *Милиционер: – Кем бар анда, чыгыгыз! – диде. Тик җир астыннан тавыш-тын ишетелмәде.* Ф.Яруллин

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса эш-хәрәкәт тавышы, шау-шу, гөрелте. *Кичен тугызлар узгач кына кайталар. Тавыш-тын чыгармыйча автобуслардан төшәләр дә... безнең чатыр алдында төнге митинг оештыралар.* З.Зәйнуллин

◊ **Тавыш-тыны ишетелмәү** Үзе турында белгертмәү; кем яки нәрсә турында бернинди хәбәр булмау. *Икенче көнне дә аның тавыш-тыны ишетелмәде*. Казан утлары. **Тавыш-тыны чыкмау** *к.* **тавыш-тыны ишетелмәү**. *Чаллы милли хәрәкәтенең бөтен тарихында яшьләрнең тавышы-тыны чыкмады.* З.Мифтахов. *Баш бухгалтер Фәридә Гайнетдинова Ошка качкан иде бит, елдан артык тавыш-тыны чыкмады*. Безнең гәҗит. **Тавыш-тыны юк** *к.* **тавыш-тыны ишетелмәү**. *Балага хәзер унбер яшь, машина-фатирның тавыш-тыны юк.* Безнең гәҗит

**ТАВЫ́Ш-ТЫНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Шаушусыз, тыныч. *Безгә бит аны гомер буе шулай тасвирлап килделәр: ул тавыш-тынсыз, куәтле, җитез*... М.Мәһдиев

2) Бик акрын, салмак, сабыр холыклы (кеше тур.) *Әмма Сәхәп кебек ата бандитның бер чынаяк сөт эчеп кенә тавыш-тынсыз, өнсез һәм мәнсез бер бәндәгә әверелүенә ышанып җитми*. Г.Гыйльманов. *Саттар агай үз кешеләрен үлсә дә читкә җибәрми, бигрәк тә Фатыйма кебек тавыш-тынсыз, җир җимертеп эшләгән кызларны*. З.Кадыйрова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тавыш чыгармыйча, тавышсыз. *Эт, Сәлимнең алдына чыгып, тавыш-тынсыз гына йөгерә башлады.* Г.Гобәй. *Йомгак кебек бөгәрләнеп, хәрәкәтсез, тавыш-тынсыз яткан бу бала ничек килеп эләккән соң монда?* Г.Гыйльманов

2) Шау-шусыз, гөрелтесез, ыгызыгысыз. *Тулай торакның 18 квадрат метрлы кысан бүлмәсендә алты җан сыешып яшәү, күршеләргә комачауламас өчен, кичләрен тавыш-тынсыз уздыру җиңелдән түгел.* Кызыл таң

3) Мыштым гына, сиздермичә, астыртын. *Аны [һәйкәлне] бер тавыш-тынсыз коеп куйдылар, белми дә калдык*. Татарстан яшьләре

4) Гаугасыз, бәхәссез, килешеп; тыныч кына, тату булып. *Банданың кәефе шәптән, эшләре майлагандай бара: бер җирдә дә каршылык күрсәтмиләр, ызгыш-бәхәс юк, салымны тавыш-тынсыз түлиләр, дәүләткә түләгәндә дә андый тәртип һәм ашыгу булмый*. Р.Мирхәйдәров. *Әлбәттә, мондый чаралар бүген беркайда да тавыш-тынсыз үтмидер*. Кызыл таң

**ТАВЫШЧАН** *с.* Тиргәшү, тавыш чыгару гадәте булган. *Үзе тавышчан да, изгелеккә авышучан.* Әйтем

**ТАГ** *и. иск. к.* **тау**. *Таг буенда, шәһәрнең читендә зур-зур фабриклар, заводлар вә тегермәннәр дә, ерактан караганда, матур күренәләр.* Ш.Мөхәммәдев

**ТАГАН** *и.* 1) Уртасына нәрсә дә булса асып кую өчен яки тышкы яктан каплап куыш ясау өчен, өске башлары үзара беркетеп бастырып куелган бүрәнәләрдән торган корылма. *Элекләрне бу урында таган асып, чатыр корган чегәннәр ятар иде*. Ф.Яхин. *Безнең якта үгез түшкәсен таганга асып куеп эшкәртәләр*. Татарстан яшьләре

2) Бер-берсенә терәтеп бастырып куелган предметлар җыелмасы. *Винтовкалар таганы*

3) Нәрсә дә булса асып кую өчен, казык, багана кебекләрнең башына аркылы салынган колга. *Койма буйларында, бәрәңге бакчаларында, бәс бәйләнгән агач төпләрендә таган астылар.* Г.Бәширов. *Болар соң таганны кайда гына асмакчы булдылар икән?* Г.Камал

4) Чүлмәк, казан кебекләрне учак турысына элү яки утырту өчен ясалган өчаяк. *Учак алдына кечкенә тимер таган белән таба куеп, аның астына ут якты.* Ә.Еники. *Бер сәгатьләп пешеп эшләгәннән соң туктап, учак яктым, алып килгән чиләгемә су тутырып, кайнатырга таган астым, көлгә бәрәңге тәгәрәттем.* Ф.Яхин

5) Атынып, тирбәнеп күңел ачу өчен, ике багана арасына яки аркылы борыска эленгән җайланма. *Телләгәнчә су керәбез, агачларга үрмәлибез, паркта таган атынабыз.* Х.Ширмән

6) *тар.* Берничә элмәкле дар. *Ягъкуб Сәет ул [угры] хатынны шул бистә таганында астырган.* Шура

**ТАГА́Н АСТЫ** *и. этн.* Таган корып, язгы һәм җәйге көннәрдә кырда уйнала торган күмәк яшьләр уены. *Шул кичне кызлар, егетләр каравыл өе янындагы чирәмлектә таган астына җыелдылар.* М.Гали. *Аннары бездә Норлатта таган асты бар иде. --- Өч көнме, дүрт көнме дәвам итер иде таган асты.* Фольклор практикасы

**ТАГАНЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **таганлау**

2) Таган рәвешенә килү

**Таганланып тору** Таган формасында булу, таганны хәтерләтү

**ТАГАНЛА́У** *ф.* Нәрсәне дә булса таган (*1 мәгъ.*) рәвешендә бер-берсенә терәтеп тезү

**Таганлап бару** Рәттән таганлау

**Таганлап кую** Алдан ук таганлау; таганлап әзер хәлгә китерү

**Таганлап тору** Әле, хәзер таганлау; вакытлыча таганлау

**ТАГАРАК** *и.* Хуҗалыкта төрле максатларда кулланыла торган, колашалап ясалган озынча зур ачык савыт. *Сыерның сөте җиленендә түгел, тагарагында.* Мәкаль. *[Гөлчәчәк курчагына]: Хәзер тагарак алып керәм дә юындырам.* Ф.Садриев

**ТАГАТЬ** *и. гар. иск.* Сүз тыңлау, буйсыну, итагать

**ТАГА́ТЬ ИТҮ** *ф.* Буйсыну, итагать итү. *Итәм тагать, күзем, күңелем тәмамән гарше әгъладә.* Г.Тукай

**ТАГАТЬЧЕ** *и. иск.* Аллага буйсынган, тәкъвалы кеше. *Галимнәр булалар --- Гыйбадәтче я тагатьче.* Г.Кандалый

**ТАГУ** I *ф.* 1) Нәрсәне дә булса икенче нәрсәгә элеп, асып беркетеп кую. *Эш көндәгечә йөк тагып торучының «Вира!», «Майна!» дип аваз салуыннан башланып китте.* Н.Хәсәнов. *– Авыл мужигы – арбага таккан дегет лагуны, – диде әти.* Г.Бәширов

2) Әгъзаларга киеп, эләктереп, бәйләп кую. *Тагын бераздан урамнар атларының ял-койрыкларына кызыл чуклар таккан егетләр, яшүсмер малайлар белән тула.* Г.Бәширов. *Әнкәй судан кайтып килә Талир тәңкәләр тагып.* М.Шиһапов. *Гөл апа әлеге чылбырны бишбылтыр ук муенына тага иде.* Н.Гыйматдинова

3) Киемгә тегеп, чәнчеп, эләктереп, бәйләп беркетеп кую (төймә, погон, асылташ һ.б.ш. тур.). *Мин бу тавышларны ирексездән тыңлыйм һәм уйлыйм: әле кырык еллар гына элек чабатага күтәрмә тагып, кырда черек бәрәңге җыеп ашап, күрше авылга җидееллыкка йөргән малайларның балалары бүген зур, якты бүлмәләрдә Бетховенны, Григны уйный!* М.Мәһдиев. *Инде шул яшел бөркәнчеген алтын тәңкәләр таккан өрфия япмага алыштырып та өлгергән.* В.Нуруллин

4) Кулга тотып йөртелә торган йорт кирәк-яракларына билгеле бер детальне эләктереп, кадаклап, бәйләп яки башка юл белән кую, кузгалмаслык итү, тотрыклы итү. *Җимле кармак тагын төште, су төбендә чүп-чар беткәнмени – Газиз аңа тагын үлән кисәге такты...* Г.Гыйльманов

5) Эләктереп киеп кую. *Кайберәүләр уйлаганча, университетта укыган башы белән «карга борыны» күтәреп, «тимер тырнаклар» тагып, багана башында йөрергә гарьләнми.* Р.Кәрами

6) Иңбашка элеп, билгә кыстырып, бәйләп, эләктереп кую. *Аннан ялтырап торган җиз төймәле аксыл сары китель кигән, биленә кылыч таккан жандарм офицеры бәреп керде.* М.Хәсәнов. *Саурыш авылының урамнары инде әллә ничә көннәр буе мылтык-җәя таккан, чалгы-сәнәк тоткан сугышчылар белән тулы иде.* В.Имамов

7) Йорт хайваннарын, шулай ук өйрәтелә торган кыргый кошларны, хайваннарны бәйләп, эләктереп кую. *Әнә Фәргать алдыннан гына бер карт каешка таккан йөнтәс ак көчеге белән бара.* Н.Хәсәнов

8) Берәр нәрсәне хәрәкәтләндерү, сөйрәү, тарттыру, өстерәтү өчен, аны башка нәрсәгә эләктереп бәйләп кую. *Челтәрле тәрәзәле вагоннар таккан состав көнбатышка таба кузгалды, брезентлы платформа өстендә кысык күзле солдат берни булмагандай басып тора иде.* М.Мәһдиев. *Аннары, без барып җиткәнне дә көтмичә, МТС тракторына арба тагып, үзләре китерделәр үрдәк бәпкәләрен.* В.Нуруллин

9) *күч.* Ияртү, җитәкләү. *Ике биясен тагып, бүген иртә белән совхозга килгән Низами бу яраны тагын ачты.* Г.Ибраһимов // Үзе белән алу, үзеннән калдырмау. *Ник соң җырлап кына сөйләшмиләр? Ник соң биеп кенә йөрмиләр? Курай, гармун, скрипка тагып, Көннәр буе «концерт» бирмиләр?* Л.Шагыйрьҗан

10) *күч.* Кемне дә булса мәҗбүри ияртеп җибәрү. *Куштан үзенә үзе табар, уңганга мулла кызын тагар.* Мәкаль

11) *күч.* Нәрсәне дә булса берәүгә көчләп бирү, тапшыру. *Фәкыйрь кеше, кемнәр сиңа иман таккан?* Г.Тукай. *Рухи кораб иңли киңлекне... Янмый калганнарын суга сала Кемдер көчләп таккан кимлекнең.* Р.Әхмәтҗанов. *Чыннан да, бюрократия һәр өлкәгә, һәр тармакка үз ихтыярын тага.* Татарстан яшьләре

12) *күч.* Кемгә дә булса, гадәттә, хурлыклы кушамат бирү. *Шигырь яздым сүгеп начар колхозны. Тәнкыйтьчеләр күз аттылар, «каралтучы» исемен тактылар.* Р.Вәлиев. *Шуңа үч итеп, ул миңа ямьсез кушамат такты.* Н.Гыйматдинова

13) *күч.* Кемгә дә булса начар сыйфат хас дип әйтү, гаепле итеп күрсәтү. *Яманга юлдаш булсаң, бәла тагар, еланга ярдәм итсәң, кулны чагар.* Мәкаль. *Тарихка тискәре ярлык тагу, алфавит алмаштыру да шул имансызлык тәсбихының чираттагы төймәләре булыр.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Таккан кебек (шикелле)** 1) Гел янда, бер дә читкә китмичә йөргән (кеше тур.); 2) Кемнең, нәрсәнең дә булса асылы, төп үзенчәлеге булып киткән сыйфат турында. *Әнә саранлыкны аңа таккан шикелле.* Ә.Еники; 3) Хәрәкәтләнергә авыр булган (кулаяклар тур.). **Тагып куелган төсле (кебек)** *к.* **таккан кебек**. *Ялтыратылган күн итекләре белән шыгырт-шыгырт басып, директор ишеккә таба атлады. Тагып куйган кебек, Габделхәй аның артыннан иярде.* Н.Фәттах. *Куллар бөтенләй тагып куелган төсле.* Ф.Садриев

**Тага бару** Әледән-әле, акрынлап тагу

**Тага башлау** Тагарга тотыну. *Мостафа бил каешына алтын кынлы кылычын тага башлагач, меңбашларның берсе барыбер дә кыю пышылдады.* В.Имамов. *Ләкин багучы, клиент сөйләгән проблемаларга кушылып, үз элементларын аңа ябыштыра, тага башлый.* Безнең гәҗит

**Тага тору** Берәр эш-гамәлгә кадәр тагу; әледән-әле тагу. *Күбрәк бомба ташлаган, танктан аткан саен, аларның күкрәкләренә «батырлык тәреләре»н тага торалар.* Ш.Алпар

**Тагып алу** Тиз генә тагу. *Җәмилне күрсәң, ак күлмәк өстеннән кара галстугын тагып алган, кыяфәт җитди, билләһи, үләм инде, үләм.* Н.Хәсәнов

**Тагып бетерү** Бик күп итеп тагу. *Күкрәккә медальләр тагып бетерү*

**Тагып җибәрү** Бөтен җире булганнан соң, өстәмә рәвештә тагу. *Башкала тәрбиясе алган, алтын погоннар тагып җибәргән улын күргәч, Мирзахан байда хәтта чак кына горурлану кебек нәрсә дә уянып куйган.* М.Хәсәнов. *[Анна карчык Машеньканың] Чәчләрен көнгә әллә ничә кат тарап, матур итеп тасмалар тагып җибәрә.* Ф.Җамалетдинова

**Тагып йөрү** Һәрдаим тагу. *Сугышка бармыйча качып ятты да башкаларныкы кебек аның да мизал тагып йөрисе килә. Кара йөз!* Н.Фәттах. *Гел кимсенә иде ул начар күрүе аркасында, ничә еллар буе «Дүрткүз» дигән кушамат тагып йөрде.* М.Маликова

**Тагып килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә, даими тагу

**Тагып кую** Тиз арада тагу; алдан ук тагу. *«Кияү егете» дигән кушамат та тагып куйганнар иде үзенә.* В.Нуруллин. *Ул үзенә берничә размерга зуррак соры пинжәк, алсу төстәге стрейч чалбар кигән, ак күлмәге өстеннән сары шакмаклы галстук тагып куйган.* М.Кәбиров

**Тагып тору** Әледән-әле яки берөзлексез тагу; хәзерге вакытта тагу. *Минем ише Дан ордены алучыларның барысына да үзе тагып тора башласа, бүтән эшкә вакыты да калмас иде аның.* В.Нуруллин

**Тагып чыгу** Барысына да тагу

**ТАГУ** II *и. диал.* Каршылык, тоткарлык. *[Кемгә дә булса] тау да тагу түгел.* Әйтем

**ТАГУН** *и. гар. иск.* Чума. *Хаҗ сәфәрендә Истанбулда тагун белән вафат булгандыр, 1813 елда.* К.Насыйри. *Амстердамда бик көчле тагун авыруы белән көненә дүрт-биш йөз кеше үлә.* Ф.Халиди

**ТА́ГЫ** *рәв.* **1.** 1) Кабат, яңадан кабатланып. *Акчәч әбинең болай да нурлы йөзе тагы яктырыбрак китте.* В.Нуруллин. *Тик белмим, алынырмы ул моңа – бер саткан кеше тагы сата.* Г.Бәйрәмова

2) Булган өстенә, өстәвенә. *– Гөлләрегез дә гөлләрегез, ниндиләре генә юк: ак, ал, кызыл чәчәкләргә төренгән яраннар, кына, тамчы гөл, ислегөл, тагы, тагы әллә нинди мин белмәгән гөлләр дә бар икән... – дип, ян тәрәзәгә таба атлады [ул].* Г.Галиева

3) Дәвам итеп, дәвамлы, өстәмә рәвештә. *Шул җәйне Гөлбаһар абыстай тагын бер малай тапты.* М.Гали

4) Булганга охшатып, икенче тапкыр. *Тагы шундый котлау языйк әле*

5) Әйтелгәннән, эшләнгәннән тыш. *Тагы шуны әйт әле син: нәрсәгә тотынсаң – шул юк, үтә дә хәерче елларга туры килде безнең балачак.* А.Хәсәнов. *Тагы нәрсә эшлибез, дип торасы юк.* Г.Афзал. *Хатын тагы нәрсәдер сөйләп маташты да, клиентның сүзгә бик һәвәс түгеллеген аңлап, башкача дәшмәде.* М.Кәбиров

6) Башка, бүтән. *Ә ир-ат өчен үзенең көндәшеннән өстенлеген тоюдан һәм әнә шул Гасимә шикелле чибәр, яшь хатынга ошаудан татлырак нинди хис бар икән тагы?..* В.Нуруллин. *Кеше өчен туган җирдән дә кадерлерәк тагы ни бар?* Н.Кәримова

**2.** *терк. функ.* Тиңдәш кисәкләрдә аталган эш-хәрәкәтнең бер-бер артлы кабатланып килүен белдерә. *Хәзер «түгәрәк»кә, аннары редакциягә, аннары тагы «түгәрәк»...* Г.Исхакый

**3.** *кис. функ.* 1) Әйтелгәннәргә шелтәләү, ачулану, мыскыллау, салкын карау, ис китмәү төсмерләре өсти. *Кызлар белән түгәрәк уен уйнарга, бигрәк тагы!* М.Мәһдиев. *Нинди кайту ди ул, сез бигрәк тагы.* В.Имамов

2) Фигыльдән аңлашылган мәгънәдә шелтәләү, җиңелчә генә ачулану, мыскыллау, борчылу, салкын карау, ис китмәү төсмерләрен көчәйтә. *Ник ачуланыйм, менә тагы.* Г.Тукай. *Кара син аны, рәвешен китергән була тагы...* Р.Галиуллин

3) Боерык фигыльдән аңлашылган мәгънәгә тынычландыру, үгетләү, юату төсмере бирә. *Син тагы әллә нәрсә уйлый күрмә*

4) Юклык формасындагы фигыль янында килеп, искәртү яки кисәтү төсмерен көчәйтеп килә. *Хуҗаңа дефицит эзләп, артыннан Кырымга ук элдермә тагы.* Н.Хәсәнов. *Шул күк җисемең белән акылдан язма тагы.* Н.Гыйматдинова. *Шулай диюгә, Нәһирнең күзләре түгәрәкләнеп китте, кеше ишетмәсен тагы дигәндәй, як-ягына куркынып каранды.* Ф.Баттал

5) Фигыль янында килеп, шул фигыльдә шаярып искәртүне белдерә. *Аталарыгыз килеп, мәәмә итеп алып китмәсеннәр тагы.* Ф.Әмирхан

6) Көтелмәгән, кирәкмәгән, билгеле булмаган нәрсәгә шикләнеп, сагаеп карауны белдерә. *Сизмәсеннәр тагы уйфикерен!* Н.Сәйяр

7) Ялгыш фикердә булганлыкны, ялгышканлыкны күрсәтә. *Ә мин тагы эшләре бетеп килә торгандыр, әллә бергә кайтырбызмы дип килүем иде.* В.Нуруллин. *Шөкер итмичә, мин анасы үлгән дип торам тагы, улы гына икән ич.* М.Әмирханов

8) Берәр эшнең, нәтиҗәнең икеле, шикле булуын белдерә. *Син, Нәкыя апа, минем сыман матур курчаклар аңа кирәк түгел, дисең тагы.* Н.Гыйматдинова

9) Уңай якка хәл ителүне белдерә. *Ярый Хак Тәгалә саклады тагы.* Г.Галиева

10) Фигыльдән аңлашылган эшхәлне хуплауны белдерә. *Ә үзе шәп уйлап тапкан тагы.* А.Мансуров

11) Ичмаса. *Ә син авыз ерып көлгән буласың тагы!* В.Нуруллин. *Нәрсә эшләсәң, ни сөйләсәң – бары да килешеп тора тагы үзеңә.* Г.Галиева

◊ **Тагы бер хәл** «Монысына гына түзәрлек» мәгънәсендә. *Малай булса, тагы бер хәл.* Г.Афзал. **Тагы килеп** Яңадан, тагын, кабаттан. *Чәй эчә башладык. Чәй янында, тагы килеп, һәркем үзенчә зарлана башлады.* Аң

**ТАГЫЛ** *и. диал.* Ювелирлык сәнгатендә бизәк төре

**ТАГЫЛМА** I *и.* Кушамат. *Кешегә тагылма тагып кую*

**ТАГЫЛМА** II *и.* **1.** 1) Машина яки тракторларга эләктереп, тагып йөртелә торган эш коралы яки машина. *Трактор тагылмалары --- эшләп чыгарган.* Г.Әпсәләмов. *Аның артыннан Әнвәр берни аңламаган җансыз тагылма кебек иярде.* Х.Камалов. *Муниципалитет ярдәме белән культиватор һәм тагылма алдык.* Әлмәт таңнары

2) *лингв.* Парлы сүзләрнең бер төре булган кабатлаулы сүзнең икенче компоненты. *Бу парлы сүзләр ике тулы мәгънәле компонентлардан ясалганнар, алар тагылма булып килмиләр, бәлки беренче компонент белән бертигез хокукта торалар.* Фән һәм тел

3) *күч.* Аерым бер төркемгә, берләшмәгә өстәмә оештырылган төркем, берләшмә. *Профсоюзларны дәүләт аппаратының тагылмалары итү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тагыла торган. *Вагоннар да, сабаннар да, тырмалар да, чәчкечләр дә – барлык тагылма инвентарь транспортларга тагылып куелган иде.* Н.Фәттах. *Ике-өч ай чамасы паркта культиватор, каток, чәчкеч ише тагылма машиналар ремонтлауда*

*катнашып йөрсә дә, Хәйдәр өйдә бер кичен дә эшсез утырмады.* В.Имамов

2) Мөстәкыйль булмаган, өстәп куела торган. *Әмма сәнгатьчелек икенчел дәрәҗәдәге, тагылма сыйфат буларак кына карала.* Милли мәктәп һәм укытуның мөһим мәсьәләләре

3) *лингв.* Кабатлаулы парлы сүз ясый торган, беренче компонентка кушыла торган. *Соңгы вакытта тагылма сүзләр бездә элекке сүзнең башындагы авазын [м] авазына үзгәртеп кабатлау белән ясала, мәсәлән, ит-мит, әзмәз.* Г.Алпаров. *Хезмәтнең морфология өлешендә галим татар телендәге сүзләрнең төзелешенә туктала, аларны өч төркемгә: ялгыз, кушма һәм тагылма сүзләргә бүлә.* Фән һәм тел

**ТАГЫЛМАЛЫ** *с.* 1) Тагылып йөртелә торган. *Тагылмалы комбайннар үзйөрешлеләре белән алыштырыла.* Кызыл таң

2) Тагылмасы булган. *Шул арада тагылмалы биш КамАЗ көнбагыш уңышы белән тулган!* Кызыл таң

3) *лингв.* Тагылма, копулятив (парлы сүзләр тур.). *Тагылмалы сүзләргә монда шактый тулы, аңлаешлы билгеләмә бирелә: «Тагылмалы сүзләр – әйтелешләре яки мәгънәләре ягыннан бер-беренә якынлыгы булган ике сүзне янәшә китереп, бер-беренә ияртеп әйтелгән куш сүзләр».* Фән һәм тел

4) Агглютинатив. *Татар теле – тагылмалы тел, һәм анда форма ясагыч кушымчалар бер-бер артлы ялгана.* Ф.Хисамова

**ТАГЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тагу** I. *Җизни бу Алты-биш Сапыйга Казаннан әллә нинди бер яхшы чана алып кайтырга кушкан икән, шул чана безнең артка тагылган...* Г.Тукай. *Атларны яланга бергәләп түгел, йөгәннәренә тагылган озын баудан тотып, берәмтекләп алып чыгалар.* В.Имамов

2) Сорамыйча гына кемнең дә булса артыннан иярү. *Килеп чыга да бер татар, үзебезнеке дип, артыңа тагыла.* Т.Миңнуллин. *Җае туры килсә-килмәсә дә, кыз артыннан тагылырга тырышты [ул].* Г.Галиева

3) Кемгә дә булса һич калышмыйча ияреп йөрү. *Баштагы көннәрдә мин укытучыма тагылып диярлек йөрсәм, соңрак инде үземне башкалар кебек үк кыю тота башладым.* М.Садыйков. *Шуннан мин, Гөлүсәгә тагылып барасым килмичә, бөтенләй артка калам.* Т.Нурмөхәммәтов

4) Белгәнрәк кешегә иярү. *Мөхәммәдьяр Хаҗитарханга баручы кәрваннарның берсенә ялгызы гына тагылып китәргә тиеш иде.* Р.Батулла. – *Газиз абый, мин сезгә тагылып кайтсам ачуланмассыздыр бит? – дип сорады Кәримә, үзен тыныч тотып.* Ф.Яхин

5) *гади с.* Кемгә дә булса кияүгә чыгу, өйләнү яки кемнең дә булса сөяркәсе булу максаты белән аның артыннан йөрү. – *Син аларга ирек кенә бир --- эләккән бер иргә тагылачаклар, – диде дә миннән ике-өч адымда туктады.* Г.Камал. *Шулай, кызым, үзем дә гаепле, тагылып чыктым мин әтиеңә...* Р.Габделхакова

◊ **Тагылган күк (шикелле, кебек, сыман)** Бер дә калышмыйча ияреп йөрү турында. *Алар безгә шулкадәр ияләште, тагылган шикелле, арттан ияреп йөриләр.* В.Нуруллин. **Тагылып килү** Ябышып кияүгә чыгу. *Синең өстән йөреп, бала табып, тагылып килде бит Булатка!* Ф.Мөслимова

**Тагыла бару** Эзлекле рәвештә тагылу; рәттән барысына да тагылу. *Нәселнең һәр кешесенә шушы кушамат тагыла бара ---.* М.Хуҗин

**Тагыла башлау** Тагылырга тотыну. *Тиешлегә дә, тиешсезгә дә «кулак токымы», «кулак ялчысы», «кулак» кушаматлары хаксызга тагыла башлады.* М.Харисов

**Тагыла тору** Даими тагылу. *Башкалар аның артыннан тагыла тордылар.* Н. Фәттах

**Тагылып алу** Көтмәгәндә тагылу. *Көннәрдән бер көнне шул тирәдә клиентлар көтеп йөри торган урам кызы Фатихка тагылып ала да --- хурлый башлый.* Казан утлары

**Тагылып бетү** Тәмам тагылу; тулысынча тагылу. *Алар коралга тотынырга вакыт җиткәнлеген, соңгы төймәнең тагылып бетүен көтүдә мәгънә юклыгын әйттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Чебиләрнең барысына да кызыл яки зәңгәр «медальләр» тагылып беткәч һәм, ниһаять, Гайшәттәй комганнан агызып торган җылы су белән кулларын сабынлап югач, Харис, юеш кулларын сөртәсөртә, урыныннан торды ---.* Ф.Баттал. *Шуннан, я бер җиңе утыртылмаган, я төймәсе тагылып бетмәгән дип, тегү срогын сузасың.* Н.Хәсәнов

**Тагылып йөрү** Билгеле бер вакыт тагылган хәлдә булу. *Ләкин, ничек кенә булмасын, дәрәҗәле исем сакланган, титул рәвешендәрәк тагылып та йөргән (әнә Гайса морза дигән кебек), хәтта безнең авылны да тирә-якта «морзалар Каргалысы» дип йөрткәннәр.* Ә.Еники. *Бу кара сакал сугыштан соң да тагылып йөрерме?* С.Поварисов

**Тагылып китү** Кинәт тагылу. *Шулай итеп, әдәбият арбасына тагылып китә язган Вәсби Алдынский таулыташлы юлда очраган беренче дыңгырдыкта ук, тәгәрмәчтән чәчрәп калган каты ләпек кебек, читкә чәчрәп төшеп калды.* Н.Фәттах

**Тагылып тору** Даими яки әледәнәле тагылу; әле, хәзерге вакытта тагылу

**ТА́ГЫН** *рәв. к.* **тагы**. *Син куян да мин куян! Без бергә ике куян! Әйдә кушыл, бер куян, Без булабыз өч куян! Әйдә кушыл тагын-тагын – Без булабыз Зәй алан!!!* Такмак. *Үзе матур, үзе уңган, комсомол әле тагын.* Җыр. *Тагын бер балачак хыялыбыз бар иде безнең.* А.Тимергалин

◊ **Тагын бер хәл** *к.* **тагы бер хәл** *Аяк кына булса тагын бер хәл иде, аның башка ягы да бар бит...* Ф.Яруллин

**ТАГЫНУ** *ф.* 1) Үзенә яки киеменә нәрсә дә булса (бизәнү әйберләре, төймә, значок һ.б.ш.) тагу. *Ат өерен сагынса, арткы аягын кагынып; ир өерен сагынса, ияр-тезген тагыныр.* Мәкаль. *Кем ул анда, кара шәлен ябынган да, Гөлдән үреп муенсалар тагынган да, Күбәләктәй, гөлдән гөлгә күчеп йөри.* Һ.Такташ

2) Бик күп итеп тагу. *Төрле бизәнү әйберләре тагыну*

**Тагына башлау** Тагынырга тотыну

**Тагынып бетү** Бик күпләп тагыну

**Тагынып җибәрү** Эшлекле, масаюлы кыяфәттә үзенә яки киеменә нәрсә дә булса тагыну

**Тагынып йөрү** Даими тагыну

**Тагынып тору** Әле, хәзерге вакытта тагыну; әледән-әле тагыну

**ТАҖ** *и. фар.* 1) Монархның хакимият символы булган, асылташлар белән бизәлгән гадәттә алтын баш киеме. *1575 елның көзендә Мәскәү Кремлендәге Успенье чиркәвендә таҗ кидерелеп, [Симеон Бекбулатович] бөтен Русьның Олуг кенәзе дип игълан ителә.* А.Тимергалин. *Иелгән башта таҗ тормас.* З.Мансуров

2) Әлеге предметның дәүләт, хакимият символы буларак орден, герб һ.б.ш.ларда ясалган сурәте

3) Асылташлардан яки шуңа охшаш нәрсәләрдән ясалган, кечкенә такыяга охшаш хатын-кыз бизәнү әйбере; диадема

4) Хатын-кыз катнашкан гүзәллек конкурсларында һ.б.ш. берәр бәйгедә җиңүчеләргә бирелә торган, еш кына күчмә булган әлеге бизәнү әйбереннән гыйбарәт бүләк. *Республиканың иң чибәр кызына энҗе белән бизәлгән таҗ бүләк иттеләр.* Казан утлары

5) *күч.* Чәчәкләрдән үрелгән такыя. *Газинур чәчәкләрдән таҗ ясап, кызының башына киертте.* Г.Әпсәләмов. *Җитмәсә, хан кызы, күкбаш чәчкәләрдән үреп, башына таҗ кигән иде...* М.Хәбибуллин

6) *күч.* Хатын-кызның толымны баш тирәли салып ясаган причёскасы, озын чәчне җыеп куюның бер формасы. *Аның өстендә --- киң итәкле, ачык изүле озын затлы күлмәк, чем кара чәчләрен баш өстенә таҗ итеп җыеп куйган.* Р.Габделхакова

7) *астр.* Кояш тотылганда, аның тирәсендә күренә торган якты бождра, алка, һалә

8) *бот.* Түгәрәк чәчәкләрдә җимшән тирәли урнашкан аерчалар (яфракчыклар) хасил иткән, гадәттә җете төстәге бождра; *русчасы:* **венчик**. *Чәчәк түшәге, үсемлек таҗ яфракларын койгач, озаеп үсү үзлегенә ия.* Агулы үсемлекләр. *Әгәр нинди дә булса чәчәк киптерергә теләсәгез, исегездә тотыгыз: бары яңа аткан чәчәкне киптерү генә яхшы нәтиҗә бирә, чөнки аның таҗ яфракчыклары ныграк берегеп тора.* Яшь натуралистларга

9) *күч.* Шул формадагы, шуңа охшаш предмет

10) *махс.* Борауның очында урнашкан пычакларның үткен, кисә торган өлеше. *Бурга --- уртасында түгәрәк тишеме булган бораулау таҗы [беркетелә].* Нефть турында хикәяләр

11) *күч.* Монарх хакимияте; монархияле илләрдә дәүләт, хөкүмәт. *Үтте, ташла! Син ул дөньяны... Көтмә тагын тәхет, көтмә һәм таҗ, Бер башыңнан таҗың алынгач.* Г.Сөнгати. *Кабыргамда ике ядрә бар. Аны «бүләк итте» дошманнар Алтын таҗга каршы чыкканда.* Ә.Ерикәй

12) *күч.* Берәр күренеш, процесс, осталык, сәнгать һ.б.ш. нәрсәнең үсешендәге иң югары нокта. *Мөхәммәдьяр иҗаты – Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятының йөзек кашы, таҗы.* Х.Миңнегулов. *Шигъриятнең таҗы – лирика.* Х.Назар

13) Берәр эшчәнлек өлкәсендә ирешелгән иң югары дәрәҗә, шуны белдергән исем, титул; гомумән шәрәфле исем. *Шахмат дөньясында киң билгеле француз драматургы Фернандо Аррабаль исә мондый белдерү ясады: ул Гата Камскийны 1996 елда шахмат таҗы өчен көрәшкә әзерләүгә ике миллион франк бирәчәк.* Р.Миңнуллин

**ТАҖГӨЛ** *и. бот.* Таҗгөлчәләр семьялыгыннан вак чәчәкләре башаклы себеркәч хасил иткән берьеллык үлән үсемлек; песи тарысы, амарант. *--- шомыртлы, баланлы, миләшле урман тугае, әрәмәлекләр җәелеп китә. Янә тагын таҗгөлләр үскән чәчәкле болыннар сузыла.* С.Поварисов

**ТАҖГӨ́ЛЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Кара алабута, төлке койрыгы кебек киң таралган, башлыча үлән үсемлекләрне берләштергән семьялык

**ТАҖДАР** *с. фар.* **1.** Башында таҗы булган

**2.** *и. мәгъ.* Таҗ иясе, монарх. *Ул – унынчы солтан, мәмләкәт тарихында тәхетне аның чаклы озак еллар буе үз кулында тоткан башка таҗдар юк.* В.Имамов

**ТАҖДА́Р ТАВЫК** *и. зоол. к.* **мисыр тавыгы**

**ТАҖИК** *и.* Таҗикстанда, Әфганстан, Үзбәкстан, Пакьстанда яшәгән, Таҗикстанның төп халкы булган, фарсы теленең бер этнолектында сөйләшә торган иран халкы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Таҗик дустым Сәидали Мамур, чуваш кызы Раиса Сарби, белорус дустым Алексей Жукович һәм башка бик күпләрнең иҗатларын да күзәтеп бара алмыйм.* Р.Миңнуллин. *Соңгы еллардагы куркыныч эш шартлары һәм арзан хезмәт хакына карамастан, биналарны да нигездә таҗик, украин һәм молдаваннар төзеде.* Л.Харрасова

**ТАҖИКИТ** *и.* Таҗикстанда табылган соры яки көрән төсле сирәк минерал

**ТАҖИ́КЧА** *рәв.* **1.** 1) Таҗик телендә. *Кәмал Хөҗәнди (Шәех Кәмалетдин Мәсгудь) Урта Азиянең Хөҗәнд шәһәрендә туган, таҗикча һәм төркичә язган шагыйрь, галим, Тәбриздә яшәгән*

2) Таҗиклар кебек, шулар рәвешендә; таҗиклар гадәте буенча

**2.** *с. мәгъ.* Таҗик телендәге; шул халыкка караган. *Дөрес, таҗикча язуларга тешем үтмәгәнлектән, мин элек аларга игътибар бирми идем.* Т.Әйди. *Таҗикча китап*

**3.** *и. мәгъ.* Таҗик теле. *Таҗикчаны әйбәт белү*

**ТАҖИР** *и. гар. иск.* Сәүдәгәр. *Көймәдә бер мөселман таҗир бар иде. Ул таҗирның углы Коръән үгрәнер иде.* К.Насыйри

**ТАҖИРЛЫК** *и.* Сәүдәгәрлек кәсебе, сату-алу шөгыле. *Мин фатирга урнашкан Җәгъфәрнең әтисе дә яшьлегендә төньякта таҗирлыкта йөргән дип аңладым.* А.Тимергалин

**ТАҖЛА́У** *ф.* Таҗ кидерү; рәсми рәвештә монарх хакимиятенә билгеләү. *Аны «җәгалә фил әрзый хәлифә» таҗы белән таҗлады.* К.Насыйри

**ТАҖЛЫ** *с.* 1) Таҗы (*1 мәгъ.*) булган, таҗ кигән

2) Рәсми рәвештә монарх булып танылган; кулында чын монарх хакимияте булган. *Сүзләремне йөрәгеңә кадамыйча Туктамам мин, канлы куллы, таҗлы хаин!* К.Тинчурин

3) Таҗы (*8 мәгъ.*) билгеле үзенчәлеккә ия булган. *Яр астында куаклыкта яшеренеп утырган энҗе таҗлы*

*миләүшә чәчәге табып бирәм, күкрәгенә кадыйм.* И.Салахов. *Кеше күзе төшмәс вак-вак таҗлы Зәңгәр чәчәк иде уемда. Түтәлләрдә үскән роза гөле Ни өчендер бүген кулымда.* Ф.Шәрипова

**ТАҖСЫЗ** *с.* 1) Монарх булырга хакы булып та таҗы (*1 мәгъ.*) булмаган, рәсми рәвештә тәхеткә утыра алмаган

2) Хакимият башыннан бәреп төшерелгән яки дәүләте яулап алыну аркасында дәүләтсез калган. *Таҗсыз корольләрне сыендыра торган яңа пайтәхетегезнең капкаларын бикләп интекмәгез. Өч көн дигәндә мин барыбер аны яулап алам!* В.Имамов

3) Таҗ (*8 мәгъ.*) яфраклары сулган, коелып беткән (чәчәк тур.). *Шәрә агачларда кырыс ныклык, Таҗсыз гөлләр елый җиргә ятып. Яшьлек үткән, картлык кагылмаган – Шундый вакыт менә, шундый вакыт.* Казан утлары

◊ **Таҗсыз король** *к.* **таҗсыз патша**. **Таҗсыз патша** 1) Рәсми рәвештә дәүләт башлыгы булмаса да, чын хакимиятне кулында тоткан кеше; 2) Халык арасында бик яратып каршы алынган, күңелләргә якын күрелгән кеше, гадәттә шагыйрь, композитор һ.б.ш. *Мөхәррир, шагыйрь вә рәссамнарны алар [поляклар] үзләренең таҗсыз патшалары итеп таныйлар иде.* Ф.Әмирхан

**ТАҖ-ТӘХЕТ** *җый. и.* 1) Патша хакимияте, монархия; патша дәрәҗәсе. *Революция булды: таҗ-тәхетләр егылды.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Берәр өлкәдә беренчелек, өстенлек. --- *татар шигъриятенең таҗтәхетен кемгә бирик, дип сорасаң, алар моңа, һичшиксез, Тукай лаек дип санарлар иде.* Х.Миңнегулов

**ТАҖЧЫК** *и. бот.* Чәчәк җимшәненең өске, уртасындагы түгәрәк төймә рәвешендәге өлеше; *русчасы:* **шпорец**. *Оча-оча күбәләкләр --- ямьле болынга килеп чыктылар, һәм һәркайсысы, үзенә ошаган чәчәккә кунып, аның таҗчыгыннан татлы ширбәт суыра башлады.* Җ.Тәрҗеманов

**ТА́Җ ЯФРАГЫ** *и. бот.* Чәчәк таҗын хасил итә торган юка тел рәвешендәге яфракчык, аерча. *Күз күреме җирдә гөлчәчәкләр, аларның кып-кызыл яки алсу таҗ яфракларыннан куе хуш ис тарала.* Т.Әйди. *Таҗ яфракчыклары бергә тоташып үскән – тоташ (хуш исле тәмәке, күгәрчен күзе) яки аерым-аерым – аерчалы (алма, чия) булырга мөмкин.* Биология

**ТАЗ** I *и. к.* **тас** I. *Карыйм, күпердән әрҗәләр, бау белән ураган төеннәр, чиләк, таз, ялгаш кебек нәрсәләр төягән һәм артына кызыл сыер таккан бер йөк арбасы шыгыр-шыгыр чыгып килә.* Ә.Еники. *Айбиби өлкән карачы хатын күрсәткән урынга утырды, шундук аның янына, җиз таз һәм комган тотып, кул юдыручы килде ---.* М.Хәбибуллин

**ТАЗ** II *с.* **1.** 1) Кутырлап, урыны-урыны белән яки бөтенләй чәчсез калган (баш тур.). *Алдан кычкырган күкенең башы таз булыр.* Мәкаль. – *Юләр, күп белгән кешенең башы таз була, – ди Баттал, көлеп.* Г.Әпсәләмов

2) Урыны-урыны белән яки бөтенләй чәчсез башлы. *Ашыккан таска төшәр, бер таз башлы кызга төшәр.* Мәкаль. *Таз башлы тәвә кошы юк минем бакчамда!* Ә.Еники

3) *күч.* Үткер, хәйләкәр, алдакчы. *Әкият герое таз малайны яисә ярлы җегетне тулпар күз ачып йомганчы бер илдән икенче илгә илтеп куя ---.* Н.Фәттах. *Вәзыйхның теге таз малай шикелле гаепне аңа япсаруларына исе китми.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чәчсез яки башында кычулы кутыр булган кеше. *Ул тазга җизни дип йөргәнче, миңа җизни дип йөргән булыр идең ичмаса.* М.Гали

2) Баштагы чәчне коя торган кычулы кутыр, кычулы тимрәү. *Кулымның сыныгы бар – җиң эчендә, башымның тазы бар – бүрек эчендә.* Мәкаль. *Ач кеше янында һәрвакыт якын күрше булып бет йөри, тиф, корчаңгы, таз авырулары яши.* М.Мәһдиев. *Мактасалар котырма, «Таз» дип әйтмә кутырга.* Т.Миңнуллин

3) *фольк.* Үткер, хәйләкәр һәм алдакчы халык авыз иҗаты персонажы. *Ханга яраган эш тазга ярамый.* Мәкаль. *Татар әкиятләрендә күп очрый торган хәйләкәр таз образын биргән «Таз» әсәре.* Г.Нигъмәти. *Әллә син, хәйләкәр таз, миннән көләргә уйладыңмы?* Ф.Яруллин

4) *күч.* Ачулану сүзе. *Гитлер дигән таз килә, Буа торган газ белән; Газ ул безгә нипачум Противогаз белән.* Р.Ишморат

**ТАЗА** *с. фар.* **1.** 1) Чагыштырмача көчле, нык. *Городской голова, дусишләре белән киңәшкәч, әҗдәһага (безга) каршы мөселман итчеләреннән иң тазаларын сайлап, балта күтәртеп җибәрмәкче булган, ди.* Г.Тукай. *Төркем башында иң таза яшүсмерләр тора.* З.Мәхмүди

2) Юантык, тулы гәүдәле (кеше тур.). *Хәзрәт бервакыт егетнең өстенә һөҗүм итәргә уйласа да, аның артык таза гәүдәсен хәтеренә алып, уйлаганын эшләргә база алмый калды.* Ф.Әмирхан

3) Симез; көр (мал тур.). *Баскыч төбендә безне таза кара айгыр җиккән рессорлы, биле сыгылмалы, тимерле арба көтә иде.* Ә.Еники

4) Көр, яңгыравык. *Гәүдәң бик төз, тавышың таза күренә.* М.Мәһдиев

5) Нык, чыдам (көнкүреш предметлары, материаллар һ.б. тур.). *Хәтәрләр күп барыр юлыңда, Таза корал булу кирәк кулыңда.* Г.Утыз Имәни. *Йорт әле таза диярлек, түбәсе кыйшайган, почмагы янтайган мунча да исән икән ---.* А.Гыйләҗев

6) Тузмаган, ертык-сүтеге булмаган (кием-салым тур.). *Кулына бераз киелгән, шулай да бик таза күлмәк --- тоткан.* Г.Ибраһимов. *Өстенә гади солдат шинеле, аягына таза солдат итеге кигән бу сөйкемле кешенең исә коңгырт яшел күзләре сине кеше буларак санга алып, хәтта якын итеп елмая.* Г.Бәширов. *Аяк киеме эченә таза, йомшак олтырак салыгыз.* А.Ситдыйкова

7) Сәламәт, авырулары булмаган. *Әмма башка җирендә бер нәрсә юк, болай сау, таза үзе.* Ш.Камал. *Мин синең һәрвакыт таза, нык, шат булуыңны телим.* М.Җәлил. *Шулай да зур соры күзләр уңмаган әле, тешләр дә таза, ак.* М. Маликова

8) Черege булмаган, нык. *Корыган агач, никадәр кисмәенчә тотсаң да, яңадан яфрак ярмый, бәлки таза агачларны гына корыта.* Г.Исхакый. *Таза чыршы, нарат төягән эшелоннар*

*тимер юлларда бүселеп утыра иде.* М.Мәһдиев

9) Нык, төзек. *Зур таза йортлар, ишегалды буйлап сузылган амбарлар, тотып тыя алмаслык шәп аргамаклар аларда иде.* Ә.Еники. *Төзек, ныклы, таза ихаталы авылларда да, җимерек, төссез, караңгы салаларда да булдым.* Ф.Яхин

10) Әйбәт, яхшы сыйфатлы итеп эшләнгән. *Батырлыкка безнең халыкка чыкмый чыгуын, иллә мәгәр тегеләрдә корал таза.* М.Мәһдиев

11) Саф, чиста; кушылмасыз, бернинди ят нәрсә кушылмаган. *Таза суда юсаң, киемең агарыр; яхшы белән сөйләшсәң – кайгың таралыр.* Мәкаль. *Тымызык таза, салкын һава, дворниклар кыштыр-кыштыр урам көриләр, шәһәр өстендә йөзләрчә төтен баганалары әкрен генә һавага сузыла, тәрәзәләре туңган якты трамвайлар шалтырап уза…* Ә.Еники

12) Чиста, керләнмәгән; чүпсез. *Төрмә бик таза да, берәү дә кереп ятарга теләми.* Мәкаль. *Куллары һәрчак таза, якасы ап-ак, значоклар таккан, итеге ялтырап тора…* С.Шәрипов

13) Көч барлыгы беленеп торган, көч белән башкарылган. *Нургали --- кешеләр йөреп таптаудан тәмам эреп изрәгән сукмак буйлап таза адымнар белән ферманың киртә капкасына таба китте.* Ә.Еники. *Степанов, күкрәгенә аскан автоматын уң кулы белән тота төшеп, таза җиңел адымнар белән безнең янга йөгереп килде.* А.Шамов

14) Урынлы. *Димәк, иптәш Юлдашев биредә аңа карата әйтелгән ачык, таза тәнкыйтьне кабул итми, үзенең бер генә, кабатлап әйтәм, бер генә хатасын да танырга теләми.* Ә.Еники

15) *күч.* Саф, эчкерсез, ихлас. *Мин сезнең чуар йөрәкле кала егетегездән саф авылның таза йөрәкле баласын мең мәртәбә артык күрәм.* М.Фәйзи. *Бу хатны да, Сибгать, Шуңар булса кирәк, Таза күңелдән Яздым сиңа.* М.Җәлил

16) *күч.* Бай, мул. *Дәүләкәндә икенче таза тормышлы башкорт безнең якын күршебез Арысланлгәрәй агай иде.* Ә.Еники. *Хәмидулла токымы корырга түгел, җиргә нык басып, таза тормышта яшәргә исәпли иде.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Көч-егәр белән, нык итеп. *Шулай булмыйча, без бит аны исерер өчен эчмибез, әзрәк ни өчен генә... тазарак басар өчен генә.* Ф.Бурнаш. *Беләм, беләм, Бикмулла, атлар синең кулга күчкәч, чыннан да таза эшли башладылар ---.* Ә.Еники

2) Каты итеп, бик нык. *«Шәйхи абзасы таза гына өшкереп җибәргәндер, ярар, таманга килер, тешләрәк булыр», – диде ул эченнән һәм, гадәтенчә, бәйләнеп сорашып та тормады.* Ә.Еники. *Мәмәшевны тагы бюрода таза гына каезладылар.* Х.Камалов

3) Яхшы, бозылмыйча, авырулар үткәрмичә, сәламәт килеш. *Таза саклаган алгы саргылт тешләре күренеп китте.* А.Шамов

4) Нык, какшамаслык итеп. *Без торгыздык һәммәсен дә Шундый аз вакыт эчендә Таза, уңай, нык итеп, – Бер ел түгел, ун ел түгел, йөз ел түгел, мең ел түгел, Мәңге торырлык итеп.* Ә.Исхак. *Кибәнне шундый очлап, шешне шундый таза утыртып куя, бернинди давылларга да бирешерлек булмый.* Ә.Еники

5) Тиешле дәрәҗәдә, күп итеп, туклыклы итеп. *Таза гына ашап юлга чыктык*

◊ **Таза Мортаза** Таза, көчле кеше турында. *Таза Мортазамыни мин сезгә [авыр эшкә җибәрергә].* Әйтем. *Бәдәнле егет Баскан уртага, Әйтерсең менә Таза Мортаза.* Ш.Галиев

**ТАЗАЛАГЫЧ** *и. сөйл. к.* **тазарткыч**

**ТАЗАЛАНУ** *ф.* Чистару, пакьләнү, тазага әйләнү. *Су буендагы камышлар, яфраклар да яңгыр артыннан яшәргән, тазаланган.* Ш.Камал

**Тазалана бару** Эзлекле рәвештә тазалану

**Тазалана башлау** Тазаланырга тотыну

**Тазалана төшү** Бераз тазалану

**Тазаланып алу** Тиз арада тазалану

**Тазаланып бетү** Тәмам тазалану

**Тазаланып җитү** Тулысынча тазалану

**ТАЗАЛА́У** *ф.* Тазарту, чистарту. *Су – тышкы ягыңны, гыйлем эчеңне тазалар.* Мәкаль. *Шуннан соң алъяпма кесәсеннән ак яулык чыгарып, яхшы ук йомшарган борынын да тазалады.* Н.Думави. *Себер, барысын тазала.* Г.Камал

**Тазалап алу** Тиз арада тазалау

**Тазалап бетерү** Тулысынча, тиешле дәрәҗәдә тазалау

**Тазалап җибәрү** Тиз генә тазалау

**Тазалап тору** Берөзлексез яки әледәнәле, яисә хәзерге вакытта тазалау

**Тазалый бару** Эзлекле рәвештә тазалау

**Тазалый башлау** Тазаларга тотыну

**Тазалый тору** Алданрак тазалый башлау

**Тазалый төшү** Бераз тазалау

**ТАЗАЛЫК** *и.* 1) Көч, куәт, ныклык. *Суксам, иңсәләрен сындырырлык тазалыгым бар, моны так сүз булсын дип лыгырдыйлар инде.* Г.Ибраһимов. *Тәрәзәдән төшкән яктылыкта абзар уртасында зур бер шәүлә пәйда булды, ул шундый зур, киң җилкәле, тазалыгы ташып торган егет асылы иде.* З.Кадыйрова

2) Юантыклык, симезлек. *Ул – Фирдәвеснең энесе, тик буйга аның белән бер чама булса да, үзенең тазалыгы белән абыйсын нык узып киткән егет.* Ф.Садриев. *Хроник авыруларның үсешенә китерүче факторлар: кандагы холестерин һәм глюкоза дәрәҗәсе югары булу, тәмәке тарту, алкогольле эчемлекләрне чамадан тыш куллану, түбән физик активлык, артык тазалык яисә симерү.* Байрак

3) Көрлек. *Терлекнең тазалыгы чамалы иде*

4) Пакьлек, чисталык. *Монда беренче күзгә бәрелгән нәрсә – тазалык, чисталык.* Г.Гобәй

5) Саулык, сәламәтлек. *Бөтен әгъзаларымда сизелә торган саулык, тазалык вә яшьлек өстенә, бөтен вөҗүдемдә үзем сизә торган бер нәфислек ---.* Ф.Әмирхан. *Барысы да бар лабаса: тазалык, тук тормыш, яраткан эш, сөйгән хатын, – я, тагын ни кирәк?* Ә.Еники. *Тазалык яклары ничек соң синең?* Ф.Яруллин

**ТАЗАРТКЫЧ** *с.* **1.** Чистарткыч; берәр нәрсәне тазарта, чистарта торган. *Мария апаның, тәрәзә тазарткыч сыекча эчеп, күзләре сукырайды.* Өмет

**2.** *и. мәгъ.* Нәрсәне дә булса тазарту, чистарту җайланмасы. *Ындыр табак-*

*ларында --- башын югары күтәреп аптырап туктап калган бодай төягечләр, бодай тазарткычлар.* И.Салахов. *Анары [ул] Бишкурайда, Иләкшидедә һәм Төйлегәндә --- өч бригадада да ике мең һәм бер мең ике йөз тонналык ашлык саклагыч, өч «ЗАВ-20» һәм «ЗАВ-40» ашлык тазарткыч салдыра, ындыр табагы ихатасына асфальт җәйдерә.* Кызыл таң

**ТАЗАРТУ** I *ф.* 1) Чүптән, кердән арындыру, чистарту. *Этнең дә теле үз койрыгын тазартырга ярый, яманның теле нигә ярый?* Мәкаль. *Сыер абзарын тазартырга, ишегалдын себерергә, малларга печән салырга әти белән чыгабыз.* И.Гыйләҗев

2) Катнашмалардан арындыру, аралау. *Хәерчегә барыбер: тазарткан тары бирделәр ни, чүплесен ни.* Мәкаль. *Ат җигеп, һәммәбезнең арышларын алып бардык та, кул-кулдан тазарттык та бетердек.* М.Гали. *– Орлык лабораториясенә дигән ашлыкны бөртекләп тазартып, чүпләп илтәсең аны, – диде ветеран Кәрим абзый яшь агрономга.* Кызыл таң

3) Симертү, көрәйтү. *Терлекләрне тазарту*

4) *күч.* Билгеле бер өлкәдә эш өчен зарарлы нәрсәләрне бетерү, юк итү. *Тазарту гаскәрне сан ягыннан азайтса да, дисциплина ныгыды, күтәрелде.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Дошманнан азат итү, аны чигенергә мәҗбүр итү, отпор бирү. *Көньякта бер айдан чак кына артык вакыт эчендә бөтен Кырым атавын дошманнан тазарттылар.* Г.Әпсәләмов. *Тазарттың син илне иблисләрдән.* Б.Рәхмәт

**Тазарта бару** Эзлекле рәвештә тазарту

**Тазарта башлау** Тазартырга тотыну. *Димәк, төнәтмә тәнне пычрак, вируслы сыекчадан тазарта башлаган.* Кызыл таң. *Кыш үтеп, язга аяк басарга өлгермибез, ломнар, көрәкләр ярдәмендә урам себерүчеләр көзен генә менә дигән иттереп түшәлгән кирпеч юлны боздан тазарта башлый.* Өмет

**Тазарта төшү** Тагын бераз тазарту; бераз гына тазарту

**Тазартып алу** Тиз генә тазарту. *Кстати, синең кулыңда көрәк тә бар икән, аның урынына без үзебездәге фабрик-заводлардагы пычраклар, чүпләрне тазартып алыйк.* Г.Камал

**Тазартып бетерү** Тулысынча тазарту. *Холестерин төерләрен, йөрәк юшкыннарын таратып, тазартып бетерә аламы соң сырхаулаган тән.* Г.Хөсәенов

**Тазартып җибәрү** Билгеле бер моментта тазарту. *Әйтерсең лә җир катламы күмеп яткан тирән чишмәне кемсәдер тазартып җибәрә дә, аннан як-якны сихәтләндерә торган саф, салкын, вакыты белән кайнар су чәчрәп чыга.* Т.Галиуллин

**Тазартып йөрү** Даими тазарту. *Имеш, сары чикмәнле мужик егетләре белән китеп, анда бәрәңге ашап, ике тиенлек чуаш ефрейторларының итеген тазартып йөргән бер бичараны, аңа кияүгә барам дип, ничә ел көт!* Г.Ибраһимов

**Тазартып кую** Тиз арада тазарту; алдан тазарту. --- *Кар этәргечләре, халык кузгалгалаганчы, урамнарыбызны ялт итеп тазартып куя.* Кызыл таң

**Тазартып тору** Даими, әледән-әле тазарту; әле, хәзерге вакытта тазарту. *Өйдәге мебельне – сервант, гарнитурларны – тузаннан даими тазартып торам лабаса.* Ә.Хәсәнов. *Әлбәттә, юл буйларын көнкүреш хезмәткәрләре тазартып тора ---.* Кызыл таң

**Тазартып чыгару** *к.* **тазартып чыгу**. *Иң тәүдә йортларны тазартып чыгардык, яшәгән урыннар ялт итеп торырга тиеш.* Р.Әбдерәшитова

**Тазартып чыгу** Тулысынча тазарту. *Бер кочак утын ябып беткәнче, ул абзарны тазартып чыкты.* Р.Батулла. *Аннан соң стеналарга чәчрәгән пычрак тапларны тазартып чыкты [ул].* М.Кәбиров

**ТАЗАРТУ** II *и.* Тазарту (I) эше, тазарту күренеше. *Су ул, төрле тазартулар, фильтрлар аша үтеп, пар казанына керә, анда парга әйләнә.* А.Алиш. *Я, нәрсә инде ул аңа бер чирлене тазарту?!* Г.Бәширов. *Соңгы тазартуны карательләр башкарды.* Кызыл таң

**ТАЗАРУ** *ф.* 1) Юанаю, симерү, көрәю, тулылану. *Грамота һәм белем ягыннан гына үсү түгел, шул өч ел эчендә ул буйга да яхшы гына ук үсте һәм гәүдәгә дә тазарды.* М.Гали. *Тишка тазарды, янбашлары түгәрәкләнде, тиресенең йоннары елкылдый башлады.* М.Мәһдиев. *[Бибисара Хәкимовна] гәүдәгә шәбәйгән, тазарган.* Н.Гыйматдинова

2) Чистару, пакьләнү. *Мондый гөнаһлардан кире кайтыгыз, Аллага дога кылып яшәгез, изге су белән тазарыгыз!* С.Алишев. *Анда баштанаяк чишенеп, юынып, тазарып чыгарга тиешсең!* Р.Батулла. *Димәк, буа суы тазарган, аңа маймычлар җибәрелгән.* Кызыл таң

3) Терелү, сәламәтләнү, савыгу. *Уфа докторына кан тәхлиле турысында бардым. Ул әүвәл тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген --- сөйләде.* Г.Тукай. *Тазарып чыгамы-юкмы – белмим…* Г.Бәширов. *Флорида авырып киткән икән, тазарсын иде инде, сезнең килү майга күчерелсә, бер дә борчылмагыз, май – матур чак, ә апрель – бик пычрак, болганчык ай.* Н.Нәҗми

4) *эвф.* Мул, рәхәт тормыш кадерен белмичә бозылу. *Тәлига кармакка эләккән балык сыман тыпырчына, тик колхоз ипие белән тазарган имамнан алай гына ычкынырмын димә.* Ф.Яруллин

**Тазара бару** Акрынлап тазару. *Ләкин Бояр ашаткан саен зурая, тазара бара, ә Нургалинең аның саен кызыксынуы көчәя: дуңгыз дигәнең күпмегә хәтле арта ала икән?* Ә.Еники. *Йөзләре алсуланып китте, тазара баруы күз алдында иде.* Х.Ширмән

**Тазара башлау** Тазарырга тотыну; тазару билгеләре сизелү. *Бала чәчәк авыруыннан тазара башлагач, «чәчәк боткасы» дигән ботка пешереп ашыйлар.* К.Насыйри. *1936 елда үпкәсенә ясалган операциядән соң Галимҗанның хәле яхшыра башлый, үпкәсендә эрен хасил булу кими, температурасы тиешле дәрәҗәгә төшә, һәм ул азрак йөзе алсуланып, тазара башлый.* З.Зәйнуллин

**Тазара төшү** Бераз тазару; тагы да тазару. *Чибәркәева сөйләшмичә тын ятты, ләкин күп ашады һәм шуңа күрә аз гына тазара да төште кебек.* Г.Әпсәләмов. *Ул тазара төшкән, йөзенә кызыллык сирпелгән.* Р.Батулла

**Тазарып алу** Тиз арада тазару; кыска вакытка тазару

**Тазарып бетү** Тәмам тазару; бик нык тазару. *Тазарып беткән бит инде синең нервлар.* М.Мәһдиев. *Дилә тазарып беткәч, гөрләтеп туй итәрбез.* Иделем акчарлагы

**Тазарып җитү** Тиешле дәрәҗәдә тазару; бик нык тазару. *Мин, яраларым тазарып җиткәнче үк, эш эзләп читкә чыгып киттем.* Г.Бәширов. *Шәхси хуҗалыкта ашатылып, симереп, тазарып җиткән дуңгыз зур, көчле була.* Г.Рәхим. *Тазарып кына җитсен, Нәҗип әле, урамга чыгып, малайлар белән сугышачак.* Ф.Яруллин

**Тазарып килү** Соңгы арада акрын гына тазара башлау. *Мин кайтканда, Кәримә ярыйсы ук тазарып килә иде инде.* Г.Бәширов

**Тазарып китү** Тиз арада сизелерлек тазару. *Сакчылар әйтә, монда килгәч, кинәт тазарып киттеләр, ди.* Х.Камалов. *Торналы һавасы шифалы, Хөршидәттәйнең каймагыннан хәзер тазарып китәр әле.* А.Тимергалин

**Тазарып кую** Берәр эш-хәлгә кадәр тазару. *[Алар] Һәртөрле табигый гимнастикалары илә гәүдәләрене ныгытып, көзгә кадәр яңадан каннарыны арттырып, буйларыны үстереп, тазарып куялар.* Г.Камал

**ТАЗАРЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **тазару** (*2 мәгъ.*). *Җылы өйгә кереп тамак туйдырып алганнан соң, ничектер, барысының да тазарынасы, юынасы, җиңеләеп каласы килә башлады.* Г.Бәширов. *Мунча кердем, тазарындым, киендем ---.* Р.Ханнанов

2) Арыну. *Андый вакытта күк йөзе, кара болытлардан тазарынып, кояш чыккан, йомшак җылы яктысы белән Гайниҗамалның күңелен яктырткан, шатландырган шикелле буладыр иде.* Ш.Камал

**Тазарына бару** Акрынлап тазарыну

**Тазарына башлау** Тазарынырга тотыну

**Тазарына төшү** Бераз тазарыну

**Тазарынып алу** Тиз генә тазарыну

**Тазарынып тору** Даими яки әледәнәле тазарыну; әле, хәзерге вакытта тазарыну

**ТАЗЗИТ** *и. диал.* Тәкәрлек, бибек

**ТАЗЛАНУ** *ф.* 1) Таз булып калу. *Аннары, хаклыкны эзләп, еллар буе, башыгыз тазланганчы йөрерсез.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Хәйләләү, алдашу

**Тазланып алу** Берникадәр вакыт кына тазлану

**Тазланып тору** Даими яки әледәнәле тазлану; әле, хәзерге вакытта тазлану

**ТАЗЛЫ** *с.* Тазы II (*4 мәгъ.*) булган. *Тазлы булса да назлы.* Әйтем. *Тазлы таз тазара.* Р.Һади

**ТАЗЛЫК** *и.* Таз II (*4 мәгъ.*) булу сыйфаты. *Тазлык – сезнең нәселдән килгән милли авыру инде ул.* К.Тинчурин

**ТАЗЫ** *с. фар. иск.* **1.** Йөгерек, тиз чаба торган. *Йосыф шулчак тазы атның башын тартты ---.* Кол Гали

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ау эте. *Заманың төлке булса, син тазы бул.* Мәкаль

2) Ау этләренең Урта Азиядә таралган төре; Көнчыгыш бурзае. *Шуннан соң шаһзәдә белән дәрвиш, икесенә ике тазы, ягъни арыслан тота торган эт алып, каекларга утырып китеп бардылар.* Ф.Халиди

**ТАИФӘ** *и. гар. иск.* 1) Фикер, мәсләк, җенес һ.б.ш.ның берлеге нигезендә тупланган кешеләр төркеме. *Башка милләтләрнең мондый киләчәкләрендә халыкның язмышы хатын-кыз таифәсеннән гыйбарәт булсын.* Ф.Әмирхан. *Бу таифә өч мәсьәләдә үзләрен «Йолдыз»га мәгълуб саныйлар: миллият мәсьәләсе, имла мәсьәләсе һәм гәзитә чыгару мәсьәләсе.* Г.Исхакый

2) Сыйныф. *Һәр икебез үлгәнче --- хезмәт таифәсен коллыктан коткаруны --- изге бурыч итеп алган идек.* М.Галәү

3) Кабилә, этник төркем. *Җәгъфәрнең кай җирдән килгән һәм нинди таифәдән вә кем угылы икәнен белүче юк иде.* Г.Тукай. *Шулай да мин безнең нәсел монголларга чаклы ук инде ниндидер бер өстен таифә (каста) булгандыр дип уйлыйм.* Ә.Еники. *Мин үзем Пенза ягыннан, мишәрләр таифәсеннән.* З.Бәшири

**ТАИФӘЛЕ** *с.* Төркемле, төркемләнгән

**ТАЙ** I *и.* 1) Бер яшьтән ике яшькә кадәрге колын. *Шул вакытта моңар иярләнгән бер тай килеп төшә.* Әкият

2) *диал.* Колын. *Яңа туган бозаулар һәм тайлар өчен махсус мичле җылы абзарлар ясалган.* М.Гали. *Димәк, гуннар атларны тай чакта ук яратып, үз итеп, сабырлыкка өйрәткәннәр.* М.Хәбибуллин

3) Кадерләп, хөрмәтләп, яратып, якын итеп эндәшү сүзе. *Карлыгач түзмәде: – Ут эчендә калдым гуй мин дә, иркә таем!* Г.Ибраһимов. *Тансыгым, кай җирең авырта соң, кашкалы колыным, таем!* А.Хәсәнов

◊ **Тай типмәгән** Үз акылында

**ТАЙ** II *и. диал.* Борынгы гадәт буенча, мишәрләрдә кыз кардәшенең бер баласын үз тәрбиясенә алган ир туган

**ТАЙ** III *и.* Курҗынның бер ягы; тәй. *Бер таена алтын, бер таена көмеш тутырып килә бу [таз].* Әкият

**ТАЙ** IV *и.* Тайландның төп халкы һәм шуның бер вәкиле. *Безне күзәтеп торган тай кызы, ярдәм итәсе килептер инде, яныбызга килде шунда.* Р.Мөхәммәдиев. *Иң беренче чиратта тай массажы сөйләп бетерә алмаслык эмоцияләр тудырган.* Тамаша

**ТАЙ-БРЕЙК** *и. ингл.* Спорт уеннарында җиңүчене ачыклау максаты белән өстәмә билгеләнгән, дәвамлылыгы төп уеннан кыскарак булган вакыт. *Җиңүчене соңгы тай-брейк уенында ачыкладылар.* Татарстан яшьләре. *Узган атна ярымфиналның дүрт уены да тигез нәтиҗәгә тәмамланганнан соң (2:2), дүшәмбе кыска вакытлы уеннар (тай-брейклар) башланды.* Безнең гәҗит

**ТАЙГА** *и. рус < төрки* Европаның төньягында, Азиядә, Төньяк Америкада үсә торган ылыслы яки катнаш урманнар полосасы. *Себернең тайгаларында без аждаһаларның башын өзеп этләргә ашаттык.* Г.Ибраһимов. *Тайга гизеп, татар ауга йөргән, Күңел ачып, аю биеткән.* Ф.Гыйззәтуллина

**ТАЙГАК** *с.* **1.** 1) Артык шома, юеш, лайлалы яки бозлавык булу сәбәпле таййдыра торган, шугак. *Түрә дәгъвачың булса, йөгенеп булмас, түбә тайгак булса, менеп булмас.* Мәкаль. *Ялгыш орынып киткән саен, агачлардан шыбырдап су коела: аяк асты пычрак, тайгак.* И.Гази

2) *күч.* Авыр; ышанычсыз, икеле; дөрес булмаган. *Әмма баш хирург*

*нигәдер икеле-микеле, тайгак фикерләр генә әйтте.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тайдыра торган урын. *Тайгактан баруы авыр*

2) Аяк асты бозлавык вакыт. *Тайгакта таяк юлдаш.* Мәкаль

**ТАЙГАКЛАНУ** *ф.* Тайдыра торган булып китү, тайгакка әверелү. *Аяк асты тайгакланып катты.* И.Гази. *Чиләкләп койган яңгыр астында тайгакланган тау битеннән ике адым да ясарга өлгермәде, аяклары таеп китеп, мәтәлеп аска тәгәрәде.* З.Мәхмүди

**Тайгаклана бару** Торган саен тайгаклану. *Аяк асты торган саен тайгаклана бара.* И.Гази

**Тайгаклана төшү** Бераз тайгаклану

**Тайгакланып бару** *к.* **тайгаклана бара**. *Аяк аслары чыланып, тайгакланып бара.* А.Хәсәнов

**Тайгакланып бетү** Бик нык тайгаклану. *Тыкрык үре сазланып, тайгакланып беткәнлектән (суны чайпалдырмыйча, түкмичә ташу мөмкин түгел), арбаны алып менү газапка әверелә.* Ватаным Татарстан

**Тайгакланып китү** Кинәт тайгаклану

**Тайгакланып тору** Даими яки әледән-әле тайгаклану; әле, хәзерге вакытта тайгак булу

**ТАЙГАКЛА́У** *ф.* 1) Баткак яки тайгак урында транспорт тәгәрмәчләре таеп чыга алмый яту. *Билгеле бер вакытта арткы өлеше тайгаклап, автобус каршы як полосага очып чыккан.* Бөгелмә авазы

2) *сөйл. к.* **таю**

**Тайгаклап алу** Бераз тайгаклау

**Тайгаклап китү** Кинәт тайгаклау. *Заһир биленнән алып өлгермәсә, Тәнзилә, тайгаклап китеп, чалкан ук барып төшәсе иде.* Р.Төхфәтуллин

**Тайгаклап тору** Билгеле вакыт аралыгында тайгаклау; әле, хәзерге вакытта тайгаклау. *Юл өсте юеш, пычрак иде. Шуңа да карамастан безнең автомашина, тайгаклап тормыйча, бик җиңел барды.* Н.Фәттах

**Тайгаклап яту** *сөйл. к.* **тайгаклап тору**

**Тайгаклый башлау** Тайгакларга тотыну

**Тайгаклый төшү** Бераз тайгаклау

**ТАЙГАЛАК** *с.* Бик шугак, тайгак. *Әмма хәзер аяк асты тайгалак, күзем дә эңгер-меңгердә начар күрә, карамыйчарак барсаң, егылуыңны көт тә тор.* Хезмәт даны

**ТАЙГАЛЫ** *с.* Тайгасы булган (ил, өлкә һ.б. тур.). *Сизелә: дустым мине үзенең тайгалы ягы белән кызыктырмакчы була ---.* З.Нури

**ТАЙГАЧЫ** *и.* Тайгада яшәүче яисә шунда кәсеп итүче кеше. *Икенче яктан, андый оста тайгачы булгач, алар нигә адашып, алга барудан, юл салудан туктаганнар?* И.Хуҗин

**ТАЙДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **таю**. *Куй, ышанма шул динсезгә, Коръәнеңнән тайдырыр, Икмәгеңне талап алыр, Үзеңне ач калдырыр.* М.Җәлил

2) *з.-сыз* Тайдыра торган булу. *Монда тайдыра*

3) Оясыннан чыгару, урыныннан чыгару, каймыктыру. *Йокыбай шундый итеп төчкереп җибәргән, антенна өстендәге ала мәче, егылып, койрыгын тайдырган.* Ф.Яруллин. *Кирәк бит димәссеңме, Нәҗип көзге каткаклыкта үз ишек төбендә егылып аягын тайдырган.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Билгеле бер урыннан тиз арада китәргә мәҗбүр итү яки юл кую. *Үзенең колхоздан качып китүе аз иде, инде тагын Ларисаны да тайдырырга тели.* М.Харлампьев

**Тайдыра башлау** Тайдырырга тотыну. *Шуннан инде тайгак юл кат-кат тайдыра башлый, егылганчыга кадәр.* З.Мурсиев

**Тайдыра төшү** Бераз тайдыру

**Тайдырып җибәрү** Кинәт тайдыру. *Чынлап та, без ишә белмибез: я ишкәк калагын суга кирәгеннән артык батырабыз (ул чагында ишкәкне каерып, көчәнеп ишәргә туры килә), я ишкәк калагын су өстеннән тайдырып җибәрәбез дә Ринат белән икебез берьюлы алагаемга чайкалып китәбез, дөбердәшеп егылабыз.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТАЙЗАК** *с.* Койрыгы коелып беткән, тәрбиясез ат. *Ир ярлы булса, яурак булыр, ат ябык булса, тайзак булыр.* Г.Әпсәләмов

**ТАЙКА** *и. этн.* Мишәр кызларының тәңкәле баш киеме. *Элек кызлар башларына тайка кигән*

**ТАЙЛАК** *и.* Икенче яшенә чыккан дөя тае, бер яшен тутырган бута. *Күкчәтау, башларыңнан күч киләме? Күч артыннан бер тайлак буш киләме?* Н.Арсланов

**ТАЙЛА́У** *ф. диал.* Колынлау. *– Ат алсак, ул тайласа, мин таена атланып йөрермен, – дигән малай.* Әкият. *Әти я колынлы бия, я бүген-иртәгә тайларга торган буаз бия алып кайта.* А.Хәсәнов

**ТАЙЛЫГУ** *ф. сир.* 1) Буын таю, каймыгу

2) Аяк таеп, тигезлекне югалту. *Тай артыннан йөргән – тайлыккан.* Мәкаль

**ТАЙМ** *и. ингл. спорт* Командалы туплы спорт уеннарының билгеле вакыт дәвам итә торган өлеше. *Беренче тайм бергә-бер хисабы белән тәмамланган иде...* Р.Батулла. *Икенче тайм исә Бохаровның яхшы уены белән истә калды.* Ватаным Татарстан

**ТАЙМ-А́УТ** *и. ингл. спорт* 1) Тайм эчендә киңәшү яисә ял итү өчен сорап алынган кыска вакытлы тәнәфес. *Бербөрсенә бирешергә теләмичә, үз активларында бер үк төрле очколары булган командалар тайм-аут алды.* Заман сулышы. *Хәтта кунакларның тренеры алган тайм-аутлар да булышмады: хуҗалар эзлекле рәвештә очко җыюларын дәвам иттерделәр.* Заря

2) *күч.* Буш вакыт, ял вакыты. *Тыгыз эш арасындагы «йомшару» вакытларында, ягъни тайм-аутларда, кайнар мунчадан, яхшы коньяктан кәефләнеп, әйбәт түләүгә махсус чакыртылган артистлардан халык җырларын җырлата --- [ул].* Х.Мөдәррисова. *--- Нәгыймә апа, ире белән киңәш-табыш итеп, башыннан кичергәнне, әле генә булып узган берәр вакыйганы сәгатькә якын түкми-чәчми сөйли, ә әтиләре Бәкер ага, сабыр гына, бүлдерми тыңлап бетергәч, тагын да биш-ун минут тайм-аут алып торганнан соң гына, «әйе, дөрес эшләгәнсең» яки «юк, ялгышкансың» дип әйтеп куя --- .* Ф.Яхин

**ТАЙМ-МЕ́НЕДЖМЕНТ** *и. ингл.* Вакытны дөрес итеп куллану технологиясе. *Парадокс түгел, тайм-*

*менеджмент!* Шәһри Казан. *Тайм-менеджмент нигезләрен аңлап, вакытыңны дөрес бүлү кагыйдәләрен ачыкларсың.* Ялкын

**ТАЙМЫН** *и.* Себердә сазлыкта, сай елгаларда йөрү өчен яссы төпле каек; *русчасы:* **таймун**

**ТАЙПА** *и. гар. диал.* 1) *к.* **таифә**

2) Нәсел шәҗәрәсе. *Ир бала – тайпа тармагы, кыз бала – тайпа чәчәге.* Мәкаль

**ТАЙПЫЛУ** *ф.* 1) Тик торганда яки тигез хәрәкәт вакытында кинәт бер якка яки артка хәрәкәт ясау. *Кискен хәрәкәттән аяк астындагы урындык та бер читкә тайпылды, һәм Таҗи ике багана уртасында һавада асылынып калды.* М.Галәү

2) Юнәлешне үзгәртү. *Яшен, үзенең башлангыч юлыннан тайпылып, тәбәнәк моржага суккан.* Яшен

3) Нормадан читкә китү, чыгу. *Психикасы тайпылган булгандыр?* Х.Камалов

4) *диал.* Буын таю, каймыгу. *[Мәдинәнең] сул кул имән бармагының буыны тайпылган, ди, төзәтеп була, ди фельдшер.* Ш.Камал

5) *күч.* Билгеле бер максаттан, идеядән, тоткан юлдан читләшү, читкә китү. *Мин, бераз читкә тайпылып, бернәрсәне искә төшереп узмакчы булам.* Н.Дәүли. *Президиум әгъзаларын сайлаганнан соң, трибунага беренче чыккан Айдарова булып Айдарова да Кадрия язып биргән тексттан беркавым да читкә тайпылмыйча гына сөйли башлады ---.* В.Имамов

6) *күч.* Үгетләүләргә, юмалауга бирешеп, фикерне, мәсләкне үзгәртү. *[Ул] Бернинди йомшатуга тайпыла торган түгел.* Х.Камалов

**Тайпыла бару** Торган саен ныграк тайпылу. *Тигез, озын басуларда җир сөргәндә, бер көйгә генә келтерәп барган мотор тавышына кайберәүләр йокымсырый башлый, һәм трактор акрын-акрын гына буразнадан читкә тайпыла бара.* Г.Рәхим

**Тайпыла башлау** Тайпылырга тотыну. *Горцеваның башлаган темабыздан чак кына тайпыла башлавын сизенү белән, кабат Газины телгә алдым.* М.Хәсәнов. *[Ул] үз вахтасы булмаса да, палубада транзистордан концерт тыңлап утырган җиреннән әледән-әле алга борчулы каранып ала һәм, баркас юлдан читкә тайпыла башласа, рубкадагыларга рульне уңга яки сулгарак торарга команда бирә.* С.Сабиров

**Тайпыла тору** Даими, гел тайпылу. *Шаярдың да читкә тайпыла тордың, ә мин исә көлүне дәвам итеп: – Син әллә бүген чит кеше белән үбештеңме? [диде].* Ә.Баян

**Тайпыла төшү** Бераз тайпылу. --- *Үзенең акыл иясе булуына масаеп (әлеге акылның Аллаһ нигъмәте икәнен онытып), инсан Хак Тәгалә күрсәткән тугры юлдан тайпыла төште.* Р.Сафин

**Тайпылып алу** Кинәт азга гына тайпылу. *Бәрәкәткә булсын дип, тустаганга беренче салынган кымызны сипкән чакта, учак ялкынының тайпылып алуы, думбра кылларыннан таралган ямансу моң --- – болар бит минем каныма, аңыма күчкән, инде мәңге кабатланмас газиз истәлекләр...* Н.Нәҗми. *Сукмактан тайпылып алган чакларымда, яки тиешсез «этлек» эшләсәм, әни төшемә керә дә шундый шелтәләп карый күзләремә, шабыр тиргә батып уянам.* Татарстан яшьләре

**Тайпылып китү** Кисәк, көтмәгәндә тайпылу. *Көпчәкле трактор, тегермән күперен чыкканда тайпылып китеп, аска – тирән сазлыкка мәтәлә.* Т.Галиуллин

**Тайпылып кую** Кинәт тайпылу. *Салих чак кына тайпылып куйды ---.* Ә.Еники. *Көтелмәгән сүздән отыры гаҗәпләнгән Фәтхелислам читкәрәк тайпылып куйды.* Ә.Баян. *Аны күргәч, Хәлимнең тәненә салкын йөгерде, ул, үзе дә сизмәстән, читкә тайпылып куйды.* Г.Гыйльманов

**Тайпылып тору** Билгеле вакытка тайпылу. *Бәлкем, янәшәбездә берәрсе ярдәмгә мохтаҗдыр, ә бит мохтаҗларга ярдәм кулы сузар өчен, көндәлек мәшәкатьләр һәм проблемалардан беразга гына тайпылып тору да җитәр иде.* Дуслык

**ТАЙПЫЛЫШ** *и.* 1) Тыныч торыштан бер якка яки артка хәрәкәт ясау күренеше. *– Азимуттан тайпылыш сизелми, – диде [ул].* А.Хәсәнов

2) Төп юнәлештән читкә чыгу аралыгы. *Хәзер исә корылманың вертикаль күчәреннән тайпылышы 1,9 м тәшкил итә.* Гасырлар авазы

3) Берникадәр үзгәреш. *«Операция»-нең бөтен детальләрен урынга чыгып нечкәләп сөйләштеләр – билгеләнгән планнан тайпылыш булырга тиеш түгел иде.* Х.Ширмән. *Татар телендә бу сүз семантик тайпылыш кичергән.* Р.Сәфәров

4) Сәламәтлектә нормаль булмаган күренеш. *Психик тайпылышлары булган кешеләрнең дә 95 проценты сулагай.* Р.Вәлитова. *Акыл үсешендә, тән-гәүдә торышында тегенди-мондый тайпылышлар булмасын өчен, бала белән туктаусыз шөгыльләнү, аны үзеңнән бер адымга да калдырмау кирәк.* К.Җәмит

5) *күч.* Төп юнәлештән, максаттан читкә тайпылу күренеше; эзлексезлек. *Пролетариат язучысы --- тормыштагы бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәчнең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.* Һ.Такташ. *Ә иҗат кешесе өчен андый тайпылыш фаҗигагә тиң.* М.Маликова

6) *күч.* Билгеле карашлардан, мәсләктән читләшү, фикерне үзгәртү күренеше. *Иң катгый таләп шул: идеологик, сәяси тайпылыш булмасын, советлар илендә яшәгән халыкның дөньяда иң бәхетле, иркле булуы шик астына алынмасын, милләтчелек баш калкытмасын!* Әдәбият

**ТАЙПЫЛЫШЛЫ** *с.* 1) Гадәти күрсәткечләрдән аермасы булган; тайпылыш күзәтелгән. *Шул заманнардан бирле без табигый вакыттан ике сәгатькә тайпылышлы аерма белән яшәдек.* Татарстан яшьләре

2) Сәламәтлек нормаларына туры килмәгән; үз-үзен тотышы нормаль булмаган. *Шуны онытмаска кирәк: тролль – көндәлек тормыштан арыган, күңеле кайткан, психик һәм социаль тайпылышлы кеше.* Л.Закирҗанова

3) Идеологик яктан дөрес түгел дип табылган. *Бергә ашап-эчеп утырганда, ул тайпылышлы фикерләр ычкындыра идеме?* Х.Камалов

**ТАЙПЫЛЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Гадәти күрсәткечләрдән аерылмый торган, үзгәрешсез. *Күп теләкләрең чынга ашып, кылган гамәлләрең тайпылышсыз икән, күңелең байый, бушлыкка чәчелми.* М.Галиев

2) *күч.* Билгеле бер идеяләргә тугрылыклы, үзгәрми торган. *Бу – идарә пунктының тайпылышсыз карары!* Р.Батулла. *Альбинаның тайпылышсыз принцибы бар: ул һәр елны өр-яңа программа әзерли, бер җырны икенче елда кабатламый.* Кызыл таң

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле бер максатка, идеягә тугры булып. *Ул [Бәһави] үзенең теләгән эзлекле рәвештә, тайпылышсыз башкарды.* А.Расих. *Я, кем шопшома гына, бер дә тайпылышсыз, туптуры гына яши бу дөньяда?* В.Нуруллин

2) Төгәл, тиешле дәрәҗәдә, җиренә җиткереп. *Бу дөнья үзенең төзеклеге, законнарының тайпылышсыз һәм төгәл үтәлүе белән сокландыра.* М.Маликова. *Тормыш бертөслерәк аккан, гореф-гадәтләр, тайпылышсыз үтәлергә тиешле кагыйдәләр буыннан буынга күчә барган, яшәү нигезе булып әнә шулар хезмәт иткән.* А.Гыйләҗев

**ТАЙПЫЛЫШСЫЗЛЫК** *и.* Даимилек, эзлеклелек, үзгәрмәүчәнлек. *Быелның беренче яртысы йомгаклары да алынган темпның тайпылышсызлыгы турында сөйли.* Казан утлары

**ТАЙПЫЛЫШЧЫ** *и.* Идеядән, карашлардан тайпылган кеше. *Син, күрәм, Казанның бер төркем уң тайпылышчылары тирәсенә эләккән булгансың...* Һ.Такташ. *Уртак көчләр белән комиссариатка 60 ка якын тайпылышчы җиткерелде, дип хәбәр итте полиция подполковнигы.* Маяк

**ТАЙТ** *иярт.* **1.** Сискәнеп сикереп китүне белдерә. *Көянтәңне асып, айт диген дә күрше коесына йөгер, тайт диген дә күрше коесына йөгер.* А.Хәлим

**2.** *ы. мәгъ.* Көтмәгәндә килеп чыгып куркытканда әйтелә. *Тайт! Нәрсә эшләп йөрисең монда? Бар, тизрәк тышка чык!* А.Әхмәт. *Кызы Зөлләә, сабый чагында өстәл астыннан чыккан кебек кенә, әллә каян: «Әтием, тайт!» – дип килеп чыгар төсле тоелды аңа.* Г.Гыйльманов

◊ **Тайт итү** Әзер булу. *Син «тайт» иткәнче, мин берне «ялт».* Ф.Садриев

**ТАЙТАК** *с.* 1) Аягында көчкә басып торган; егылырга торган. *Яңа туган тайтак бәрән*

2) *күч.* Сүзендә, вәгъдәсендә тора алмыйча, әле тегенең, әле моның сүзенә карый торган. *Тайтак егет*

**ТАЙТАКЛА́У** *ф.* 1) Аягында басып тора алмау, чайкалып тору

2) *күч.* Сүздә тормау, фикерне гел үзгәртеп тору

**Тайтаклап алу** Берникадәр вакыт тайтаклау

**Тайтаклап китү** Кинәт тайтаклау

**Тайтаклап тору** Озак вакыт яки әледән-әле тайтаклау

**ТАЙТОЯК** *и.* Кирказончалар семьялыгыннан тамырчалы, кыска сабаклы, тай тоягына охшаш яфраклы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **копытень**. *Кайчандыр тайтояклар үсеп утырган бу үзәнлек Мурманск – Печенга шоссесының ачкычы булып әвереләде.* Г.Әпсәләмов. *– Без тайтояк һәм миләүшә суын җыйдык, – дип җавап кайтарды тегеләре.* К.Тәхау

**ТА́Й-ТУЛАК** *җый. и.* 1) Төрле яшьтәге тайлар. *Яшь тай-тулак байтал янында кешнәшә, тешләшә, тибешә.* Р.Батулла

2) *күч.* Шук, шаян яшьләр, егетҗилән. *[Бики:] Әнә күрәсең, җыен тай-тулакның шул тирәдән китүе юк.* Н.Исәнбәт

**ТАЙФУН** *и. кыт.* 1) Тын океанның көнчыгышында була торган җимергеч өермәле давыл. *Әмма шушы кечкенә җиребездә дә тыныч түгел, шомлыкиеренке, кешеләр, тыннарын кысып, гүя зур тайфун килеп җиткәнен көтеп торалар.* Ә.Еники. *Бер заманны купты давыл, тайфун көче, Актарылды диңгез төбе, диңгез өсте.* Г.Афзал. *Җитмәсә, Япония ягында тайфун котыра, шимбә – якшәмбе яңгырлы булачак, дигән иде җирле халык.* Туган як

2) *күч.* Бик көчле һөҗүм, кузгалыш. *Пожар балкыр, утлы тайфун калкыр Халкыбызның бөек үченнән.* Ә.Ерикәй

3) *күч.* Ачулы усал кеше. *Мәнә әле ун-унбиш минут кына элек Гаптери исемле тайфун үтеп китте.* Ф.Яхин

**ТАЙФУ́Н КОШЫ** *и. зоол.* Давыл кошлары семьялыгыннан зур канатлы, кыска койрыклы диңгез кошы: *русчасы:* **тайфунник**

**ТАЙЧАНУ** *ф.* 1) Таеп китеп авышу. *Ул кичә бу урында бераз тайчанды*

2) Тайпылу. *Миңнулланың күз алдында дага ялтырап китте: ул, кулын баш очына күтәреп, чак кына тайчанып өлгерде.* И.Гази. *Садыйк тәрәзәдән бераз читкә тайчанды.* Ш.Камал. *Куышканда, кинәт тайчанып, тоттырмый калу, сикергәндә, җитди кыяфәт белән йөгереп килеп, җәп астыннан чыгу кебек гадәтләре турында сөйлиләр.* И.Нуруллин

3) *ялг.* Таяну. *– Ярый... – диде дә, бер аягына тайчанган көе, икенчесен алгарак җибәреп, тәмәке урый башлады [ул] ---.* Ш.Камал

4) *башлыча юкл. форм. күч.* Нәрсәдән дә булса тыелу, баш тарту. *Куркып-посып үлгәнче, тайчанмый тауга менеп үл.* Мәкаль. *Мин аны, әле кичә иртә белән генә исән-сау хәлендә күргән кешене, мәет хәлендә күрергә куркам, җаным тайчана, берничек тә аягым тартмый иде.* Г.Бәширов. *Шул бәхет хакына туган илен калдырып китүдән дә тайчанмаган иде.* М.Кәбиров

5) *күч.* Уңайсызлану, тартыну, оялу. *Нәҗипне больницада нибары бер атна яткырдылар, «хәлегез түзәрлек, инфаркт юк, анализлар әйбәт, ә больницада урын җитми» дип, тайчанмыйча әйтеп бирде дәвалаучы врачы.* А.Гыйләҗев. *Туры җавап бирүдән тайчана [ул].* Т.Галиуллин

**Тайчана башлау** Тайчаныргa тотыну. *Нәфисә хәзер Салтанатбикә белән очрашудан тайчана башлады.* Ә.Мохтар

**Тайчана төшү** Бераз тайчану

**Тайчанып алу** Аз гына тайчану

**Тайчанып калу** Кинәт тайчану. *...Тора-бара Радикның Фәриткә «әти» дип әйтүдән тайчанып калырга тырышуы сизелә башлады...* З.Мифтахов

**Тайчанып китү** Кинәт тайчану. *Ишек ачылып китү белән, Гарәпшаның аяклары зур каталардан ычкынып, үзе артка тайчанып китте.* Ш.Камал. *Трюмның авызына җитеп, инде чыгарабыз дигәндә генә, мичкә тайчанып*

*китеп өстемә төшә язды, ярый әле аякны терәп калдым: уң аяк кысылды, параша чайкалып өстемә түгелде.* И.Салахов

**Тайчанып куюю** Кинәт тайчану. *Кыз киек тырнагына эләккән болан баласыдай сискәнеп, тайчанып куйды, әмма егетнең киң күкрәгеннән, таза кулларыннан ычкына алмыйча тынып, буйсынып калды.* Җ.Дәрзаман

**Тайчанып тору** Вакытлыча яки әледән-әле тайчану. *Вакытлыча гына булса да партия һәм төркемнәргә бүленүдән тайчанып торырга чакырам.* Р.Мөхәммәдиев

**ТАЙЧЫНУ** *ф. к.* **тайчану**. *Берәү шундый хәлдә калса, бөкрәер, йомылыр, өметеннән өзелер, барысы да бетте, дигән сылтау артына посар, актив хәрәкәттән тайчыныр һәм шулай итеп үзен үзе начар хәлгә куяр иде.* Х.Камалов. *Бөтен белгәнеңне сөйләргә керешсәң, болар сине аңгырага санаудан да һич тайчынмыйлар.* Ә.Гаффар

**Тайчына бару** Акрынлап яки торган саен ныграк тайчыну

**Тайчына башлау** Тайчынырга тотыну. *Соңгы араларда инде күзгә туры карап сөйләшүдән тайчына башлады ул.* Казан утлары

**Тайчына төшү** Бераз тайчыну

**Тайчынып алу** Азга гына тайчыну

**Тайчынып килү** Билгеле бер вакытка кадәр тайчыну. *Һәдия, төрле сәбәпләр табып, өзеп кенә җавап бирүдән тайчынып килде ---.* Казан утлары

**Тайчынып кую** Кинәт бераз тайчыну

**Тайчынып тору** Вакытлыча яки әледән-әле тайчыну. *Йомшаклык сизсә, һәрчак үз асылында булды, бер дә кәнфитләнмичә, бу хакта төрттереп тә, турысын әйтеп салырга да тайчынып тормады.* И.Гыйләҗев. --- *Үз иҗади көченә ышанган шагыйрь теләсә кайсы катлау кешеләре, танылган абруйлар белән конфликтка керүдән, ачы, усал бәясен күзләренә әйтүдән тайчынып тормый.* Т.Галиуллин

**ТАЙЯР** *хәб. сүз. гар. иск.* **1.** Әзер. *Тимер дружина беренче сигнал бирү белән большевикларга каршы сугышка чыгарга тайяр тора.* К.Тинчурин. *Иптәш хәрби комиссар! Карл Маркс исемендәге кызыл полкта барлыгы 633 кеше әзер. Беренче, икенче, өченче, дүртенче роталар, пулемётчы һәм элемтәче командалар сезнең хезмәтегезгә тайяр.* Н.Исәнбәт. *Тулаем номенклатура дигән таифә (каста) теләсә кемгә, теләсә нинди властька да яраклашырга тайяр ул!* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* 1) Итагатьле, хөрмәт күрсәтә торган; күндәм, карусыз. *Бәйләнештек без гомердә яр булып, Ул миңа һәм мин аңа тайяр булып.* Ф.Бурнаш

2) Ярдәмгә һәрвакыт әзер булган

**ТАЙЯ́Р БУЛУ** *ф.* Әзер булу. *Аны аерым фатирда тотармын, һәммә эшенә хезмәтчеләр тайяр булып торырлар, дип әйтә, ди.* Ш.Камал

**ТАЙЯРЛЫК** *и. иск.* 1) Әзер булу, әзерлек. *Мондый тайярлык вә саклык нәрсәгә һәм ни өчен?* Г.Тукай

2) Күндәмлек, карусызлык

**ТАК** I *с.* 1) Җөп булмаган, калдыксыз икегә бүленми торган (бөтен сан тур.). --- *Я так иҗекләрдә урнаштырылуга тартымлык күрсәтәләр.* Г.Нигъмәти. *Җөп түгел шул, так, диләр.* И.Гыйләҗев. *Йорт номерлары туры килмәсә дә (берсе – так, берсе – җөп), мин нигәдер «Теремок» шушы бәләкәй кибет урынында булгандыр дип күз алдыма китерә идем.* А.Тимергалин

2) *диал.* Ялгыз; буйдак. *Егерме лә яшем, тактыр башым, Җирән атым – ялгыз юлдашым.* Җыр. *Үзем Ситдикъ, атам Ягъкуб, бабам Исхак, Кардәшләрем җәфасыннан мин калдым так.* Кол Гали

**ТАК** II *и.* Биналарның стенасында түгәрәк кашага формасындагы архитектур бизәк. *Ике кашың гүя ике так икән.* Г.Кандалый. *Бинаның гадилеге һәм җыйнаклыгы, катлар һәм алардагы такларның, архитектура детальләренең динамикалы композициясе --- хәйран күренеш бирә.* Казан утлары

**ТАК** III *и. иск.* Тәхет. *Идегәй әйткән көн килде. Чыңгызның куйган хан тагы кан тагы булып әверелде.* Дастан

◊ **Такка салу** Егет белән кызны кавыштыру, беренче кич кундыру. *Таң алды булгач, егет белән кызны салалар такка.* Ф.Баязитова. *Таң алды, такка салу – егет белән кызның беренче мәртәбә кавышулары, беренче кичләре.* Милли-мәдәни мирасыбыз

**ТАК** IV *и. диал.* 1) Бушлык

2) Юксыллык

◊ **Такка таяндыру** Тәмам бөлдерү; өметсез хәлгә төшерү. *Аннан соң хикмәт юлламада гына түгел бит әле, такыр кесә белән ерак юлга барыбер кузгалып булмый, ә ире чирләп яткан айлар гаиләне тәмам такка таяндырган иде.* М.Маликова

**ТАК** V *иярт.* Ике каты әйбер берберсенә бәрелгәндә ишетелә торган саңгырау авазны белдерә. *Сәялләнеп каткан каты куллар Так-так суга кызу тимергә.* М. Гафури

**ТАКА** *и. диал.* **1.** Ирсез яки хатынсыз, гаиләсез кеше

**2.** *кис. мәгъ.* Бөтенләй (ялгызлык тур.). *Така ятим*

**ТАКАЙ** *и. диал.* Апа, түти. *Бездә хатын-кыз ролендә хатын-кызлар булдылар: Гөлчәһрә такай, Хәдичә такай, --- Мәдинә такайлар ---.* Н.Исәнбәт. *Татар халкының кайбер этник төркемнәрендә ана ягыннан кардәшлекне белдерә торган нагач «абзый» һәм такай (тай) «түти» сүзләре дә очрый.* Р.Әхмәтьянов

**ТАКЕЛАЖ** *җый. и. голл.* 1) Зур судноларының аркан, трос, чылбыр һ.б.ш.лар кебек барлык кирәк-ярак җиһазы. *Көлтә йөген бастырык белән басканда, нибары бер-ике төен белгән малайлардан унөч төрле диңгез төенен бәйләп күрсәтү, шлюпкалар, җилкәннәр, такелаж, рангоут, шпангоутлар кебек баш бетәрлек нәрсәләр турында гыйлем таләп итәлә иде.* М.Мәһдиев

2) Авыр йөкләрне күтәрү, төшерү, күчерү өчен кирәкле җайланмалар

**ТАКЕЛАЖЧЫ** *и.* Йөк күтәрү-төшерү эшләрен башкаручы эшче. *Такелажчы бармак белән «уйный», Сикерткәли аны һәр якка, Машинистның күзе шул бармакта, Ә куллары тимер рычагта.* Ш.Маннур

**ТА́КИ** I *терк. фар. иск.* Теләкне белдергән иярчен җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Изге гадәтләреңне тот, таки гайреләр күреп тәгълим алсыннар.* К.Насыйри. *Һәр*

*шәһәрдә үзенә күрә чүплек башы була бит, әйбәтләп шунда җәеп кенә карагыз, таки борыныгызга сатлык Моратлар белән эштән чыккан Ф.Сәйманилар сасысы кермәсен.* Г.Тукай

**ТА́КИ** II *кис. рус сөйл. к.* **тәки**. *Чукынды, мин әйтәм, таки адәм мәсхәрәсе булдык, дим.* М.Фәйзи. – *Кара, карт гвардиянең йөрәге таки түзмәгән бит, – дип куя иде [ул].* Г.Әпсәләмов

**ТА́К ИТҮ** *ф.* Саңгырау аваз чыгарып, каты итеп бәрелү. *Ике яктан так итеп таш кире кайтты, ә менә барган якта әллә никадәр шак-шок килеп түбән төште.* Д.Бүләков

**ТАККАРАВЫЛ** *и.* Каравылчы итеп билгеләнгән кешенең, постын күздән ычкындырмыйча гына, тирә-якка качкан яки аның урынына килеп басарга омтылган уенчыларның берәрсен билгеле бер вакыт эчендә куып тотарга тиеш булуына корылган күмәк уен. *Кая барсам да, мине, мулла баласы дип, халык башка малайлардан аерганга, хәтта җыеннарда яшьтәш кызларым илә таккаравыл уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.* Г.Тукай. *Сафа белән Саҗидә, җитәкләшеп, тыгыз төркем эченә кереп киттеләр. Түгәрәк уртасыннан чыккач, таккаравыл уенын уйнаучыларга кушылып, беренче пар булып бастылар.* М.Галәү

**ТА́К КҮБӘЛӘК** *и.* Дулкынчалар семьялыгыннан саргылт яки соргылт ак алгы канатларының уртасында кара тимгеле булган ефәкче күбәләк; *русчасы:* **непарник**

**ТАККЫЧ** *и.* 1) Авыл хуҗалыгы коралларын атка, тракторга яисә вагоннарны тагу өчен махсус җайланма. *Ә Раиф Мөхәммәдиев эретеп ябыштыручы Сәлимҗан Шаһиәхмәтов белән үзенә 22 метрлы таккыч (сцепка) әзерли, --- таккычны үз сызымнары буенча ясаган иде.* Ватаным Татарстан. *Бу чор эчендә 117 данә үзйөрешле машина һәм таккыч тикшерелде.* Дуслык

2) Төймә урынына кулланыла торган кыска таякчык, тияк

**ТАКЛЫ** *и. к.* **таккаравыл**

**ТАКЛЫК** *и.* Ялгызлык. *Бары тик шундый мәхәббәт ия кодрәтле көчкә: әүвәл таклыктан коткара, соңыннан – үкенечтән...* Р.Харис

**ТАКМАЗА** *и. фольк.* 1) Халык авыз иҗатының көйләмичә әйтелә торган такмак, рифмалаштырылган шаян эчтәлекле сүзләрдән гыйбарәт кече жанры. *Төрле бәет, такмаза, җырларның тууына сәбәп булган Галиуллин машинасы әнә шул инде.* Г.Кутуй. *Табышмак әйтешле дисеңме, җыр җырлауны, такмаза чыгаруны – барысы да шунда.* Ш.Мостафин

2) *куч.* Эстетик кыйммәте булмаган шигырь; назым. *Шулкадәр күп китаплар арасында, мәсәлән, бер күзгә эләгерлеге юк икән. Кайсысына карама, шунысы, фаразан, урыс такмазасы.* Ф.Әмирхан. *Әмма шигыребез такмаза гына түгел, форма ягыннан төзек, эчтәлеге белән мәгънәле булсын.* Л.Ихсанова

**ТАКМАЗАЧЫ** *и.* Такмаза чыгаручы; такмаза әйтүче. *Штатка такмазачы ике артист Фәйзи Ковалинский һәм аның кызы Роза Юнысовалар алына.* Ш.Рахманкулов

**ТАКМАК** *и.* 1) *тар. этн.* Туйда бирәсе бүләкләр тутырылган сумка

2) *этн.* Туй бүләге өләшкәндә әйтелә торган җор сүзләр, куплет һ.б.

3) Башлыча бию көйләренә башкарыла торган кыска җыр; фольклор жанры. *Үзе бии, биегән көйгә башын чайкап такмак әйтә ---.* Г.Бәширов. *И әнкәй, бигрәкләр дә тәмле итеп юындырасың Рамилне, ул такмакларны каян табып бетерәсеңдер?* А.Әхмәтгалиева

4) *куч.* Коры рифмага гына корылган, эстетик кыйммәте булмаган шигырь; назым, мәнзумә. *Үз союзларына язмаган һәм язмаячак картларны да, мәкалә яки шакмаклап такмак сырлаштырган кешеләрне дә, хәтта тәрҗемәчеләрне дә кабул итеп кенә торалар икән.* Ф.Баттал. *Моны ишеткәч, Кәримә еларга җитеште: – Бу минем шигырьләрем бит! Нинди такмак булсыннар?* Ф.Яхин

**ТАКМАКЛА́У** *ф.* 1) Такмак әйтү. *Бәс, мин, яңа теле чыга торган баланың аңлашылмас такмагы кеби, вәзенсез-нисез бер бәет такмакларга керештем.* Г.Тукай. *Балалар килүчеләрне алдан өйрәнеп куйган «Ишек бавы» куплетларын такмаклап каршы алалар.* М.Бакиров. *Такмак такмаклар өчен сигез ел укыдыңмы?!* Н.Гыйматдинова

2) Җыр, шигырь кебекләрне такмак рәвешендә әйтү, көйләү. *Фәхрине шәйләп алгач, телендә тагын бер-ике ялкынлы фраза биетте дә шигырь сыманрак такмаклап әйтте ---.* Ф.Яхин. *Мәсәлән, төрки халыкларның бик күп борынгы йолаклыкларын чагылдырган йола – мәрхүмнең җеназасы, соңгы юлга озату йолаларында кешенең яхшы якларын әйтеп, образлы итеп такмаклап җырлау, сыктауның акын авызыннан башкарылуы бик үзенчәлекле.* Ф.Баязитова

3) Бер үк сүзләрне билгеле бер ритмга салып әйтү, кабатлау. --- *Йөри торгач аптырап, Салмак атлап, шәп атлап, Әллә нинди бер сүзне Алып киткән такмаклап.* Ә.Фәйзи. – *Тик тә тормагыз, күп тә урмагыз, башагы эләксә ярар! – ди-ди такмаклап, Гыйбаш абзый узып киткәли.* Г.Бәширов. *Ана түзмәде, күрше-тирә ишетмәслек кенә аваз белән тилмереп такмаклады: – Алдама инде, улым, алдама!* Ф.Баттал

4) *куч.* Бер төрле ритм белән нинди дә булса тавыш чыгару. *Аяклар астындагы каты кар такмаклап шыгырдый.* Р.Мөхәммәдиев

**Такмаклап алу** Бераз гына такмаклау. *Тимеркәй беркөнне, сөйләшеп утырганда, әнә шушы такмакны такмаклап алды.* З.Мәхмүди. *Әле җырлап җибәрә иде аның әнкәсе, әле шигырь такмаклап ала...* А.Мансуров

**Такмаклап бару** Билгеле бер вакыт дәвамында такмаклау. *Чү, нишлим мин, тутыйкош кебек, бер сүзне такмаклап барам лабаса.* Р.Габделхакова

**Такмаклап бетерү** Бик күп такмаклый башлау. *Тиз арада әллә ниләр такмаклап бетерделәр.* С.Поварисов

**Такмаклап җибәрү** Такмаклый башлау. *Төхфәт абзый, җаена мач китереп дигәндәй, такмаклап та җибәрде: «Чәй эчүнең шарты бар – бавырсак та коймак, Сары майга манып-манып, кунак алдына куймак!»* Ә.Еники.

*Кемдер хәтта: – Бәхетленең кунагы соңлап килеп зурлады, – дип такмаклап җибәрде.* Д.Бүләков

**Такмаклап йөрү** Билгеле бер вакыт дәвамында такмаклау. *Мин тагын абыемның якасына ябыштым: «Нәрсә такмаклап йөргәнеңне әтигә әйтәм», – дидем.* В.Юныс. *Мәйсәрә түти башкасына тешен кысып булса да түзәр иде дә бит, ә менә оныгының аңа: «Кыек күз, чалыш авызлы карт убыр», – дип такмаклап йөрүенә генә йөрәге нык әрни иде.* Н.Хәмидуллина

**Такмаклап китү** Кинәт тамаклап җибәрү. *Ул күз яшьләрен сөртә-сөртә такмаклап китә ---.* Н.Сәйяр

**Такмаклап кую** Кинәт такмаклап алу. *[Ул] Такмаклап та куйды: «Киткән кызлар кире кайта – бар да безнең бәхеттән».* Х.Камалов. *[Бала] – Әз эшләлгә, күп йоклалга, Тәмле асалга ялатам, – дип такмаклап куйды.* Г.Галиева

**Такмаклап тору** Даими яки әледәнәле такмаклау; әле, хәзерге вакытта такмаклау. *Инде кул чабып, такмаклап торучы кызларның тамаклары карлыкты, инде менә-менә кемдер арып аяктан егылыр сыман тоела башлады.* Ф.Латыйфи. *Ямьсез җикеренеп, такмаклап торган Нурулла, үз ачуы белән мавыгып, тау аланындагы сазлыкка бата башлавын сизмәде дә.* Г.Гыйльманов

**Такмаклап утыру** Әле, хәзер такмаклау, озак вакыт такмаклау. *– Әй Ходаем, бу күперне ничек салыйм да, агачларны ничек үстерим дә, алмаларынхөрмәләрен ничек пешерим, – дип такмаклап утырганда, әлеге кыз килеп җитә.* Әкият. *Әгәр чыннан да, атна буе бикләнеп, шигырь такмаклап утыргансыз икән, димәк, сез нормаль түгел!* М.Маликова

**Такмаклый башлау** Такмакларга тотыну. *Мәрьям дә элеп алып такмаклый башлады ---.* М.Хәсәнов. *Әллә бәбидән дә көнләшеп куйдымы, еламсырап такмаклый башлады [ул] ---.* Г.Галиева. *Башта ике төркемгә бүленү өчен санашасың, тезелеп басасың да, ике командирның берсе такмаклый башлый.* Р.Газиз

**Такмаклый бирү** Бернигә карамый такмаклау. *– Нигә сиңа тиң булмадым икән мин, Мирсәет... – дип такмаклый бирә Рауза.* Р.Мөхәммәдиев

**Такмаклый тору** Әледән-әле, өзлексез такмаклау. *Бала булса – шук булсын, шук булмаса – юк булсын, дип такмаклый торгач, догадан китте бугай.* Безнең гәҗит

**ТАКМАК-ТАКМАЗА** *җый. и.* Төрле такмак һәм такмазалар. *Эшләре бер дә алга бармый иде. Шуннан соң кызлар сөйләшә, шаяра-көлешә башладылар, табышмак әйтештеләр, аннары такмак-такмаза әйтештеләр, әкият сөйләделәр.* М.Галәү. *Ошбу көнне малайлар вә кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларга такмак-такмаза әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.* Р.Ягъфәр

**ТАКМАКЧЫ** *и.* 1) Такмаклар чыгаручы; такмак әйтүче. *Такмак кеби гади тезмәләрне Тукай шактый күп язды: Галимҗан Ибраһимов та, Дәрдемәнд тә аны «такмакчы» диделәр, бер укуда халык аңлый торган ул такмаклар, бәлки, Некрасовтан башланадыр?* Р.Батулла. *Аю биетеп йөрүчеләр 5 – 6 кеше, алар арасында курайчы, думбрачы, җырчы, такмакчы, көлдерүчеләре булган.* Р.Ягъфәр

2) *күч.* Эстетик кыйммәте булмаган шигъри тезмәләр язучы, назымчы. *Шигырь алып килдем әле, дип кереп кара алар хөкеменә! Салам тибрәтеп язучы... такмакчы...* Ф.Яхин

**ТА́КСА** I *и. нем.* 1) Эш, хезмәт өчен төгәл билгеләнгән түләү нормасы. *Извозщикка утыра, хәбәре юк таксадан: егерме тиен җиренә бер сум бирә кибеттәге кассадан.* Ш.Мөхәммәдев. *Исәп-хисапны без халыкара такса белән йөртәбез: йөз доллар!* А.Хәсәнов

2) *күч.* Чик, күләм. *Монда билгеле бер такса куелмаган, хәлеңнән килгәнчә булышасың.* Алабуга нуры

**ТА́КСА** II *и. нем.* Кыска аяклы, озынча гәүдәле бүлмә яки ау эте токымы һәм шул токымнан булган эт. *Башым һәм кулларым йөгереп китеп, аякларым артта калса, мин такса этенә охшап калачакмын...* С.Гаффарова. *Австриядә Генерал Эди кушаматлы такса токымлы эткә 22 яшь икән инде.* Татарстан яшьләре

**ТА́КСАЛАУ** *ф. күч.* Такса (I) кую, такса билгеләү

**Таксалап бетерү** Тулысынча таксалау

**Таксалап кую** Алдан ук таксалау

**Таксалап тору** Даими яки әледәнәле таксалау

**ТАКСА́ТОР** *и. лат. махс.* 1) Товарга бәя куючы белгеч

2) Таксация белгече. *Урман буйлап агач санап, үлчәмнәр үлчәп, кайсы җирдә нинди эш башкарыласын билгеләп йөрүче, урманчыга эш йөкләүче һәм киләчәккә планнар коручы хезмәт иясен таксатор дип атыйлар икән.* Шәһри Казан

**ТАКСА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* 1) Сәүдә оешмаларында товарның бәясен билгеләү эше

2) *а.х.* Урманда агачларны санау, урманны бәяләү эше

3) Берәр нәрсәнең күләмен, зурлыгын, сыйфатын билгеләү. *Без токымнарның беразын, таксация ясап, Мәскәүгә җибәрәбез.* Х.Камалов

**ТАКСИ** *и. ингл.* Такса (I) белән кеше йөртә яки йөк ташый торган автомобиль. *Ашыгып кием элгечкә килде, пальтосын алды, өстенә киде, клубтан чыкты да, троллейбус та көтмичә, такси алып редакциягә чапты.* Г.Минский. *Күп уйлап тормадым, такси ялладым да шунда киттем.* А.Хәсәнов. *Такси шофёры, Фәләхнең хәлен чамалап, машинасы инде тулы булуга карамастан (дүрт кеше утыра иде анда), Фәләхне утыртып алып китте.* В.Нуруллин

**ТА́КСИС** *и. гр.* 1) *биол.* Ирекле хәрәкәт итүче түбән төзелешле үсемлекләрнең, хайваннарның, шулай ук кайбер күзәнәкләрнең (лейкоцит, сперматозоид) яктылык, дым, электр, химик матдәләр тәэсирендә хәрәкәтләнү реакциясе. *Уңай таксис*

2) *лингв.* Төрле эш-хәрәкәтләр арасында вакыт мөнәсәбәтләрен белдерә торган категория

**ТАКСИСТ** *и. рус сөйл. к.* **таксичы**. *Таксист шикләнеп миңа борылды.* М.Мәһдиев. *Башым гына түгел, үзем дә уйга күмелеп беткәнмендер, күрәмсең, кайтып җитүемне дә таксист әйткәч кенә абайладым.* Ф.Баттал.

*Рәхәтләндереп, үз җаегызга, үз бәһасенә йөрткән таксист очратканыгыз бармы?* Р.Батулла

**ТАКСИЧЫ** *и.* Такси йөртүче. *Таксичы риза булмый.* Р.Батулла. *Иң күп рөхсәт алган таксичы «Матрица»да эшли ---.* Туган як

**ТАКСО́МЕТР** *и. рус* Таксида эшне һәм юл бәясен күрсәтү өчен куелган счётчик. *Таксист әле таксометрын сүндермәгән, анда нибары ике сум җитмеш өч тиен генә күрсәтә иде.* В.Нуруллин. *Әлеге канун нигезендә, такси хезмәтендә эшләүче кеше махсус рөхсәт алырга һәм машинасында таксометр урнаштырырга тиеш.* Безнең гәҗит

**ТАКСОМОТОР** *җый. и. рус* Такса түләнүе исәбенә кеше йөртә яисә йөк ташый торган машина. *Быел таксомотор оешмалары белән очрашып, аларны уртак ассоциациягә туплау күздә тотыла.* Ватаным Татарстан. *Тик бу кагыйдәләр таксомотор транспортына һәм йөртергә өйрәтү машиналарына карамый.* Заман сулышы

**ТАКСУ** *ф. диал.* Бик азаю, бетү алдында тору

**Таксый бару** Торган саен таксу

**Таксып бетү** Бик нык таксу

**ТАКСЫК** *с. диал.* Бетеп килгән һәм шуңа күрә саклап тотылырга тиешле. *Барда – каксык, юкта – таксык.* Әйтем

**ТАКТ** I *и. нем.* 1) Метрик музыкаль берәмлек. --- *Монда көйнең тактларына, тавышларына карата ябык-ачык иҗекләрнең дөрес килүе дә роль уйный.* М.Җәлил. *Көй уңаена салмак кына чайкалып килә-килә дә, такт алышынганда кинәт кенә мимикасын үзгәртеп, кырт борылып куя.* В.Нуруллин

2) Бер-берсеннән тигез аралыкта билгеле бер тәртип белән башкарыла торган хәрәкәтләр. *Кулларын кысканда, аякларын гаскәриләр формасында такт белән китереп басканга күрә, бу исәнләшү бик матур чыкты.* Ш.Камал. *Инде хәзер старттагы тамаша тәмам, яхшылап шомартылган уңайлы трассалар өстендә бер дәрт, бер такт белән шуган чаңгы тавышлары гына яңгырый.* Бөгелмә авазы

3) Эшләү ритмы. *Монда барлык көчне төзек тактка салып баралар.* Ш.Камал

4) *махс.* Нинди дә булса бер механизмның эш циклында аерым бер өлеш. *Пар машинасының пешкәк такты*

5) *лингв.* Сөйләмнең ритмик-интонацион бүленеше, паузалар белән аерылган кисәге. *Чәчмә әсәрдә фраза синтагма (такт) чиге белән дә туры килергә мөмкин, бер төшенчә бер сүз (кар; буран), ике-өч сүз белән дә (салкын һава; Киек Каз Юлы) белдерелә ала.* М.Саттарова

**ТАКТ** II *и. нем.* Кешеләр белән мөнәсәбәттә, мөгамәләдә чама хисе; сөм, нәзакәт, әдәп. *Гаять четерекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин, шулай да, ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр.* Ә.Еники. *Мин шулчакта аның үз-үзенә бикләнүе, астыртынлыгы турында да әйтмәкче булдым, ләкин такт саклап тыелып калдым.* Ф.Садриев

**ТАКТА** *и.* **1.** 1) Бүрәнәне берничә тапкыр буйга телеп әзерләнгән, ике капма-каршы ягы да тигез яссы өслектән торган төзелеш материалы. *Лагерьның бер җирендә иске такталардан, аннан-моннан гына кадаклап, бер сарай кебек нәрсә ясалган.* Н.Дәүли. *Гамилләргә әйләнеп кайтканда, такта китергәннәр иде инде.* А.Тимергалин. *Ике ир әллә каян озын киң такта табып килде.* В.Имамов

2) Кайбер предметларның әлеге материалдан гыйбарәт булган, шуннан ясалган, төзелгән өлеше, детале. *Соңгы дүрт як стенаны да карадым. Стенасы яңарак кына ясалганга охшап, һәрбер тактасына «Маварәэннәһердә сәяхәт» дип язганнар.* Г.Тукай. *Ләүкә такталары аларны көтеп кызган: аһ-ух, әллә-лә, мәллә-лә, анакайларым ла.* Р.Батулла

3) Шул материалдан ясалган, аерым максатларда кулланылган кирәк-ярак. *Шулай да шахмат тактасы янына утырырга үзләрендә көч тапты алар.* В.Нуриев. *– Иртәгә сәгать сигезгә приказлар тактасы янына килергә онытмагыз, – дип, директор чыгып китте.* М.Мәһдиев. *Куна тактасы зурлыгындагы «Бабаевский» дигән шоколадлар төяп, «Украина»га кайттык.* И.Гыйләҗев

4) Корылмаларны эчтән яки тышкы яктан тышлау материалы, тыштакта; *русчасы:* **вагонка**. *Әнисе килеп киткәннән соң, нишләптер, Надяның авылга йөрүе ешая башлады, һәм, ни хикмәт, өйдәге юк-бар эшләрне сәбәп итеп, иренә кайчан балконның эчен такта белән эшләп бетерәсен, кайчан ваннада ремонт башлап җибәрергә кирәклеген искәртеп, үзе генә кайтып килү ягын карый иде.* Г.Бәйрәмова

5) Шул материалның кисәгеннән хәтерләткән яссы әйбер. *Пластик такталар җитештерү*

6) Уку йортларында өсйөзенә язусызу башкарыла яки төрле язулы кәгазьләр беркетеп куела торган җиһаз; табло. *Әгәр ул: «Теманы кем сөйләргә тели?» яки: «Такта янына кем чыга?» – дип сораса, иң элек мин кул күтәрәм!* В.Нуруллин. *Укытучылар да мине тактага чакырмадылар.* А.Тимергалин

7) Зур яссы монитордан гыйбарәт электрон җиһаз. *Компьютер, интернет, интерактив такта һәм башка инновацияләр артыннан куып өлгерергә дә кирәк бит.* Безнең гәҗит

8) *диал.* Бер кыеклы түбә. *Без, без, без идек: без уникә кыз идек, бер тактага җыелдык – таң атуга коелдык (Уникә кыз йолдызлыгы).* Табышмак

9) *күч.* Ябык кеше. *Аның хатыны – такта*

**2**. *с. мәгъ.* 1) Тактадан (*1 мәгъ.*) торган; шуннан эшләнгән. *Бакчаның бер ягында биек такта койма.* Н.Дәүли. *Әмма язмыш балаларга мәрхәмәтлерәк караган: урман авызында ук алар «Спорт базасы» дип язылган ике такта йорт янына килеп чыгалар.* А.Тимергалин

2) Яссы, такта (I) рәвешендә прессланган. *Такта чәй, ситсы, галош кебек әйберләрне Кара Чыршыга шыпырт кына шушы хатын торгыза иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Яссы һәм каты. *Такта җир*

4) *күч.* Ябык. *Алар, гадәттә, җирән чәчле, соры, төссез күзле, кызыл чырайлы, озын борынлы, такта гәүдәле була.* Х.Мөдәррисова

**ТАКТАБАШ** *с. диал.* **1.** Бер генә кыеклы, бер генә якка авышлы (түбә тур.). *Тактабаш алачык*

**2.** *и. мәгъ.* Бер генә кыеклы корылма. *Тактабаш төзеп кую*

**ТАКТАЛАНУ** I *ф. төш. юн. к.* **такталау**. *Рәнҗү-каргышларын берьюлы ачып салган хуҗалар да, ярым караңгы, тынчу өй дә, чыпта кадакланган дымлы ишек тә, тышкы яктан такталанып, пычкы чүбе тутырылган вак-вак дүртәр өлгеле тәрәзәләр дә, чаршау алып ташланганлыктан шәрәләнеп калган сәке дә --- – барысы да күңел биздергеч иде.* М.Хәсәнов

**Такталанып тору** Даими яки әледән-әле такталану; әле, хәзерге вакытта такталану

**Такталанып яту** *сөйл. к.* **такталанып тору**. *Такталанып яткан саллар, карсак борынлы баржалар, эрелеваклы пароходлар торган саен ешрак очрый.* Р.Низамиев

**ТАКТАЛАНУ** II *ф.* 1) Тыгызланып кату. *Яңгырдан соң туфрак такталану*

2) Авыр эштән йомшаклыкны, сыгылмалылыкны югалту. *Бил такталану*

3) Бик нык пычрану, керләнү, майлану. *Эш киеме такталану*

**Такталана бару** Торган саен ныграк такталану

**Такталана башлау** Такталанырга тотыну. *Такталана башлаган куллар*

**Такталана төшү** Тагын да такталану; берникадәр такталану

**Такталанып бетү** Бик нык такталану. *Шәйхаттар бабай --- такталанып беткән кулы белән [Шәехтайның] ялын сыйпап куйды.* Г.Гобәй. *Кайчан гына күрмә, [каравылчының] өстендә такталанып беткән каткан кием.* Х.Кәрим

**Такталанып китү** Кинәт такталану. *Көчле яңгырдан соң җир өсте такталанып китте, иңкел урыннары ялтырап ката башлады.* Г.Бәширов

**ТАКТАЛА́У** *ф.* Такта белән тышлау (мәс., каралты-кураны)

**Такталап бетерү** Тулысынча такталау

**Такталап кую** Тиз генә такталау

**ТАКТАЛЫ** *с.* 1) Тактасы булган, тактага ия. *Тагын да харабрак әллә кем кыяфәтенә кереп өлгермәсен бу диярәк, теге «Начальник» такталы ишекне ачып, эчке якка уза бардым.* Ф.Яхин. *Сәнгать мәктәбе интерактив такталы булды.* Туган як

2) Тактадан эшләнгән; такта белән ябылган, тышланган һ.б. *Кердек, куе караңгы агачлар арасында ниндидер калкулыклар, иңкүлекләр, черегән такталы чардуганнар, мүкләнгән, дымлы, яшькелт ташлар бар иде.* М.Мәһдиев. *Аның күз алдына үзләренең калтайган такталы капкасы, җимерек таш келәте, җимерек кар базы, авып-түнеп барган лапаслы абзарлары, келәсенә чыбык тыгып киткән өйләре килде.* А.Хәлим

3) Яссы итеп прессланган, такта рәвешендәге. *Бер-берендә эчтән янап, ананас, тавык ашап, Балеар утрауларында ясалган мәшһүр шәраблар эчеп утырырга мөмкин; бер-береңә ихтирамың ташыган хәлдә хозур кылып, тозга манып, мич бәрәңгесе ашап, такталы кытай чәе эчеп утырырга мөмкин...* М.Мәһдиев

**ТАКТАЛЫК** *с.* **1.** 1) Такта итеп ярырга ярый торган. *Кемгә йортлык, кемгә такталык агач кирәк, кемгә утыны кирәк...* Ә.Сафиуллин. *Монда буралык нарат, имән, такталык чыршы хәстәрлик, кул астында барда эшләмәсәк, яңадан каян табарбыз?!* Р.Хәбибуллина

2) Билгеле сандагы тактага җитәрлек. *Дүрт такталык нарат*

3) Билгеле сандагы тактадан торган. *Бакча турысын узуга, инеш киңәйсә дә, анда бик үк калын булмаган субайлар сугылып, киңлеге өч кенә такталык басма сузылган.* Т.Нурмөхәммәтов

**2.** *и. мәгъ.* Такта итеп ярырга ярый торган материал. *«Гөлнадия апа, талашмыйбыз да, кычкырышмыйбыз да, алып каласың», – диде. «Алып калмыйм, миңа такталык, араталык алып килсәң – алып калам, ә сырны ашамыйм».* Безнең гәҗит

**ТАКТА-ТОКТА** *җый. и.* Төрле такталар, такта кебек әйберләр. *Тактатоктаның чуты юк бит монда.* А.Гыйләҗев. *Бар булган аермалары шунда гына: күбесенең тирә-ягына такта-токтадан яссы түбәле бәләкәй генә куышлар әмәлләгәннәр дә шуларга морҗа чыгарганнар.* В.Нуруллин

**ТАКТА́ЯРГЫЧ** *и.* **1.** Такта яра торган машина. *Су көче белән эшли торган бу тактаяргыч колхозның бөтен төзү эшләренә кирәкле тактаны җитештереп тора ала икән.* М.Гали. *Терсәкләре дә тактаяргычны хәтерләтә.* Р.Сәгъди

**2**. *с. мәгъ.* Такта яра торган. *Тактаяргыч ыстан*

**ТА́КТИК** I *с.* Тактикага бәйләнешле. *Шул ук көнне Кимов тактик өйрәнүләргә чыгып киткән.* Г.Әпсәләмов. *Без противогазлар астык, мылтык макетларын күтәреп, кырга тактик дәресләргә чыктык, атакага бардык...* М.Мәһдиев. *Сәясәтенең ул төп стратегик юнәлешләрен билгеләп бетермәгән, әмма тактик планын күзаллап куйган иде инде.* Ф.Яхин

**ТА́КТИК** II *и. гр.* 1) Тактика (*1–2 мәгъ.*) белгече

2) Тактикалы, уйлап эш итүче кеше. *Ә хатын-кыз сәясәтче ул – тактик.* Өмет

**ТА́КТИКА** *и. гр.* 1) Сугыш сәнгатендә аерым бәрелешләрне әзерләү һәм сугышу осталыгын тәшкил иткән төп алымнар. *Сугышчан тактика тәртибе буенча, лейтенант Бикиев ротасына капитан Баранов батареясы беркетелгән.* Х.Камалов. *Шулар өстенә, ихтимал булган дошман авиациясенең дә техникасы үзенчәлекләрен, тактика үзгәлекләрен белеп торырга тиеш алар.* Р.Мөхәммәдиев

2) Конкрет максатларны күздә тотып, конкрет урында һәм вакытта сугыш алып баруның теориясен һәм гамәлен өйрәтә торган фән, предмет. *Сугыш игълан ителгән көнне без гомуми хәрби тактикадан имтихан бирергә тиеш идек.* Г.Сафиуллин

3) Спортта җиңүгә ирешүнең төрле ысуллары һәм алымнары. *Барганда, ярты юлыбызны үзебез катнашырга тиешле ярышлар төрен сайлауга, икенче яртысын стратегия һәм тактика билгеләүгә багышладык.* Ә.Мушинский. *Уен башыннан ук алар актив һөҗүмгә күчте, һәм мондый тактика уңай нәтиҗәләрен озак көттермәде.* Шәһри Казан

4) *күч.* Максатка ирешүдә төрле чаралар һәм көрәш алымнары җыелмасы. *Я, бу соң шигырь яза торган урынмыни? Кайда соң тактика?* Н.Исәнбәт

5) *күч.* Уйлап эш итү. *Логика, тактика, аннан да бигрәк дипломатия кирәк мондый очракта.* С.Рафиков

**ТА́КТИКАЛЫ** *с.* Тактикага ия, билгеле тактикага нигезләнгән. *Ләкин акыллы, тактикалы Сарсымбай аны тыйды: – Кулы белән кылганын муены белән күтәрер, адәмне үлгәч сукмиләр, – диде.* Г.Ибраһимов. *Командаларның икесе дә көчле, кискен һәм кыю оештырылган һөҗүмнәр, мәйданның һәр почмагында оста тактикалы уен күрдек бу очрашуда.* Әлки хәбәрләре

**ТА́КТИКАСЫЗ** *с.* **1.** Тактикасы булмаган, тактикага таянмаган; дөрес тактика кулланмый, тактиканы белми торган. *Крыймовның Донбасста вакытта кайбер тактикасыз моментлары булгалады ---.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* Тактикадан башка; тактиканы белмичә. *Һе, «Кыз»ны тактикасыз гына кулга төшереп булмас кебек күренә бит әле.* Х.Камалов

**ТА́КТЛЫ** I *с.* **1.** Иплән, уйлап эш итүче; әдәпле, нәзакәтле. *Нинди әйбәт, тактлы ул.* Х.Туфан. *Директорыбыз Әнвәр абый – бик тактлы кеше, кайчандыр безнең авылда да укыткан, этиәниемне, апаларымны яхшы белә, юккабарга дәрес бүлдермәс.* Н.Әхмәдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Иплән, уйлап; әдәп белән. *Бик тә тактлы эш итү сорала*

**ТА́КТЛЫ** II *с.* Билгеле сандагы тактлардан (I) торган; билгеле сандагы тактларга корылган. *Ике тактлы гына булса да, аңа вальс әйләнергә мөмкин сыман.* З.Мәхмүди

**ТА́КТЛЫЛЫК** *и.* Тактлы булу, иплән, уйлап эш итүчәнлек, әдәплелек, нәзакәтлелек. *Тактлылык һәм башкаларны хөрмәт итү аларга тумыштан бирелгән ---.* Ватаным Татарстан. *--- Сабырлык, тактлылык, тирән белем – чын хөрмәткә лаек укытучы сыйфатлары.* Туганайлар

**ТА́К-ТОК** *ият.* Берәр каты нәрсәгә икенче каты әйбер белән сукканда, дагалы ат килгәндә һ.б.ш. очракларда чыккан каты һәм саңгырау авазны белдерә. *Коридордан үтеп йөрүче аяксызлар идәнгә так-ток бәргән култык таякларының тавышы гына ишетелә иде.* Х.Камалов

**ТА́КТОЯКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Тоякларын барлыкка китерә торган бармаклары так санда булган эре имезүче хайваннар отряды. *Тактояклыларның скелетында умрау сөяге юк.* Биология

**ТАКЫЛ** *и.* 1) Ырмау ясый торган ышкы. *Такыл белән эшләп куюю*

2) Тар озын такта формасындагы озынлык үлчәү һәм туры сызык сызу коралы. *Эштә акыл да кирәк, такыл да кирәк.* Мәкаль. *Такыл белән сызып, кырый-кырыйларын балта белән читлә.* Н.Хәсәнов. *«Кеше такыл тактасы ясарга да шуннан өйрәнгәндер әле», – дигән Нурулланың әтисе Миңнулла абый.* Р.Газиз

3) Ювелирлык эшендә көмеш яки алтын чыбык сузу өчен кулланыла торган корал

**ТАКЫЛДАВЫК** *с. сөйл. к.* **такылдык**. *– Бөтен кеше дә синең кебек такылдавык булса, кем тыңлап торыр иде икән, – ди икенчесе аңа каршы.* Г.Әпсәләмов

**ТАКЫЛДАТУ** *ф.* 1) Так-так иткән авазлар чыгару. *Автоматымны кысып тоттым, такылдатып корып куйдым, иптәшләремне ул-бу булмаска кисәтеп.* М.Мәһдиев. *Тукран шулкадәр тиз вә каты такылдатты ки, кыз түзмәде, башын күтәреп карады.* М.Хәбибуллин

2) Берәр нәрсәгә бик каты бәргәләү, суккалау. *Клавиатура такылдаталар.* Т.Миңнуллин

**Такылдата башлау** Такылдатырга тотыну

**Такылдатып алу** Бераз такылдату. *Автоматларын да такылдатып алалар.* М.Хәсәнов

**Такылдатып тору** Даими яки әледән-әле такылдату; әле, хәзерге вакытта такылдату

**ТАКЫЛДА́У** *ф.* 1) Так-ток итеп тору. *Тагын балталар шакылдады, ышкылар чыжлады, мүк кагучыларның имән чөйләргә китереп суккан тукмаклары такылдады.* Р.Газиз

2) *күч.* Сөйләү. *Я, такылда инде алай бик кыбырсып торгач!* Г.Бәширов. *Шәфи Алмас әле озак такылдады.* Г.Әпсәләмов. *Ату телевизордан иртә-кич шул хакта такылдыйлар.* И.Диндаров

3) *күч.* Бик тиз, бик күп сөйләү; кабат-кабат бер үк сүзне сөйләү. *Бер эшен бетерүгә икенчесенә тотына, шул арада үзе такылдарга да, көләргә дә, хәтта җырлап алырга да җаен таба.* Ә.Еники. *– Исән-имин генә яшисезме, дәгъва-үтенечләрегез юкмы, тормышыгыздан риза-бәхилме? – дип, гадәттәгечә, ишектән керә-керешкә саескандай такылдарга керешә [ул].* М.Әмирханов

4) *күч.* Сер тотмау, сүз йөртү. *Гена, әлбәттә, анда бераз артыгын такылдады, ләкин барыбер уңга-сулга лыгырдап йөрүдән хатын-кызларга да, сату итүче иргә дә моннан мәгънә юк.* Ә.Мушинский

5) *күч.* Әһәмиятсез яки мәгънәсез сүзләр сөйләү

**Такылдап алу** Бераз такылдау. *Трактор, кара төтен ургытып, каты гына такылдап алды.* Н.Фәттах. *Мин әле сезгә әйтәсе сүзләремнең яртысын да әйтергә өлгермәгән идем, ә менә бу адәм, кешенең сүзен бүлеп, үзенекен такылдап та алды.* В.Нуруллин

**Такылдап бетерү** Бөтен нәрсә турында такылдау. *– Чү, Мөнирә, машинада ук әтиеңә бөтен яңалыкларыңны такылдап бетермә, – диде Суфия ханым, көлемсерәп.* Г.Әпсәләмов. *Гапсаттар әйтәсен такылдап бетермәгән иде, без аның дәвам итүен көттек ---.* Ф.Яхин

**Такылдап китү** Көтмәгәндә такылдый башлау. *Хуҗабикә, сорауга туры җавап бирүдән тайчынып, әмма бу темага кагылуына һич кенә дә үкенмичә, Зөлфияне мактап такылдап китте.* Т.Галиуллин

**Такылдап кую** Көтмәгәндә бераз такылдап алу. *Алар ягыннан көндез бер яки ике тапкыр туптан аталар, теләр-теләмәс кенә дигәндәй, пулемётлары такылдап куя.* Г.Әпсәләмов

**Такылдап тору** Даими яки әледән-әле такылдау; әле, хәзерге вакытта такылдау. *Өзлексез такылдап торган тәгәрмәч тавышлары күңелле көлү астында күмелеп кала.* Г.Әпсәләмов. *– Туктаусыз эше турында гына такылдап торган ир белән яшәгән хатынга Алла ярдәм бирсен, – диде Кифая, өйне яңгыратып.* М.Маликова

**Такылдап утыру** *к.* **такылдап тору**. *– Шуларны микрофон алдында тутыйкош кебек такылдап утыр инде, – дип зарлана иде ул.* Э.Гадел. *Җәйгән, җәйгән, бар, такылдап утырма.* Т.Гыйззәт

**Такылдый башлау** Такылдарга тотыну. *Шунда ук, апаларына сарылып, такылдый да башладылар [алар].* Ә.Еники. *Поцелуйкин тагын нидер такылдый башлаган иде, Назимов аны бүлдерде ---.* Г.Әпсәләмов. *Турганов та немецча такылдый башлады.* Х.Камалов

**Такылдый бирү** Бернигә карамый такылдау. *Редиска, суган йолыкканда, Мәлих мондагы матурлыкларга да соклануын тыя алмыйча, баягы төслерәк такылдый бирде ---.* Ә.Баян. *Уегызга ни килсә, шуны такылдый бирегез.* М.Әмирханов

**ТАКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **такылдау**. *Нәрсә бирedә такылдашасыз?* Т.Гыйззәт

**Такылдаша башлау** Такылдашырга тотыну. --- *Сугыш кызып китте, ике яктан да пулемётлар такылдаша башлады.* К.Рәхим

**Такылдаша бирү** Бернигә карамый такылдашу

**Такылдашып алу** Бераз такылдашу

**Такылдашып кую** Кыска гына бер ара такылдашу

**Такылдашып тору** Даими яки әледән-әле такылдашу; әле, хәзерге вакытта такылдашу

**Такылдашып утыру** *к.* **такылдашып тору**

**ТАКЫЛДЫК** *с. сөйл.* **1.** Күп сөйләүчән; лыгырдык. *Эшлексез кеше такылдык булыр.* Мәкаль. *– Карале, сабакташ, – диде такылдык Гатия, аны бер читкәрәк тартты.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Күп сөйли торган, лыгырдык кеше. *Такылдыкның теле туйдыра.* Мәкаль

**ТАКЫЛЛА́У** *ф.* 1) Тигез зурлыктагы чыралар телү

2) Тирене, күнне тар тасмаларга кисү

3) Тактаны ышкылау

4) Сырлау (ювелирлык эшендә)

**Такыллап алу** Бераз такыллау

**Такыллап тору** Даими такылдау; әле, хәзерге вакытта такыллау

**Такыллый башлау** Такылларга тотыну

**ТАКЫ́Л-ТАКЫЛ** *иярт.* Өзлексез такылдау турында. *Такыл-такыл утыру*

**ТАКЫ́Л-ТАКЫЛ КИЛҮ** *ф.* Туктаусыз такылдау

**ТАКЫМ** I *и. госм. иск.* 1) Төркем; оешма; команда. *Бу дөнья бер такым вәхшиләргә җае сафа улды.* Г.Тукай. *Эш кызу иде. Бер такым мирза, зыялылардан төзелгән мөселман комитетына каршы көрәшергә кирәк иде.* Ш.Әхмәдиев

2) Комитет. *Фабрикада эшчеләр такымы*

**ТАКЫМ** II *и. иск.* 1) Тезнең арты куыш ягы, тез асты. *Атка менгән кешенең тай менеп такымы суелмас.* Мәкаль

2) Шпора. *Такым кысып атына, Карамыйча артына Качкан икән йөз батыр.* Н.Арсланов

**ТАКЫР** *с.* **1.** 1) Тапталып, тыгызланып тигезләнгән (юл, сукмак һ.б. тур.). *Юл такыр, тузан юк, күк алаша, эченә кату төшүдән горт-горт иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта...* Ә.Еники. *Чирәмле такыр гына юл.* К.Миңлебаев

2) Йөрергә уңайлы. *Ата юлы балага такыр.* Мәкаль

3) Тигез итеп төбеннән урылган. *Үткер корыч, үз артыннан киң дуга шикелле такыр эз калдырып, чыжылдап, үлән сабакларын кырып салды, дымсу, яшел печән, бергә җыелып, сул аяк янына килеп өелде.* Н.Фәттах

4) Сөрелгән һәм чәчелми калдырылган (басу, кыр тур.). *Такыр җиргә, бүлгәләп, Бодай таратасыңмы? Чын күңелдән сөясеңме, Әллә шаяртасыңмы?* Җыр. *Оста токарь кырган кебек, Кыр өсте тигез, такыр.* Ә.Исхак

5) Үсемлеге, үләне-агачы булмаган. *Анда берни күренми: ярым үле карурман юкка чыккан, аның урынында ниндидер аксыл төстәге иксез-чиксез бушлык, такыр чүл җәйрәп ята иде.* А.Тимергалин

6) Чәче, төге төптән, пеләш итеп алынган. *Гали абзый фуражкасын салып, ак яулыгы белән такыр башын сөртте.* Г.Әпсәләмов. *Шамил белән Мансур икесе дә такыр башлы, авызлары ерылган.* В.Имамов

7) Өслеге берни белән дә капланмаган, чиста. *Ә инде тапсаң, гөмбәнең дымсу такыр башына кунган яфрак кисәкләрен әкрен генә сыпырып төшерәсең, ләкин кисеп тырыска салырга ашыкмыйсың.* Н.Гыйматдинова

8) *күч.* Буш, эчендә, өслегендә бер әйбер дә калдырылмаган. *Такыр кесәдә һәм күңелдә ямьсез бушлык.* Р.Низами. *Кибет киштәләре күргәзмә экспонатлары куярдай такыр иде.* Н.Әхмәдиев

9) *күч.* Буш; бик аз; чамалы, житәрҗитмәс. *Казна сандыклары такыр булса да, Сафа Гәрәй хан Сөембагны төзү өчен үз хәзинәсеннән күп кенә акча бүлеп бирергә булды.* Р.Батулла. *Ваклап-ваклап кемдер акыл сата, үзенә дә такыр акылны.* Р.Миңнуллин

10) *күч.* Бик начар, түбән дәрәҗәдә. *Аның [Галинең] русчасы такыр иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тигезләп тыгызланган яки тапталган урын. *Безнең урам такыры – җиз комганның бакыры.* Җыр. *Күзе иярләшә төшкәч, тутай күрде ки, алачыкның эче киез белән эчләнгән, тышы да киез белән тышланган; идәндәге ком балчыгына хәтле алынган: такыр салкынча, такырга тула җәелгән.* Р.Батулла

2) *геогр.* Чүлләрдә, коры далаларда кибеп беткән сулыкларның төбе. *Ком сахрасы тозлы такырга, анысы ак балчыклы үзәнлеккә тоташты.* Т.Әйди

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Тапталып, тигезләнеп. *Елга буе кояшка каршы тау бите булгач, кары күптән эрегән, кара җир кеше аягы белән тапталып, тап-такыр булып кипкән...* Ә.Еники. *Өздереп чап, чалгың уйнап торсын, такыр калсын покос арасы.* С.Сөләйманова

2) Тигез итеп; төбеннән кырдырып (чәч, мыек, сакал тур.). *Мыекны такыр кыралар, үстерәләр сакалны, Кеше күрмәстәй булганда ялтыраталар бокалны.* Ш.Мөхәммәдев. *Нигә кирәк икән юләрләргә мондый калын чәч, акыллы башлар такыр йөргәндә?* Ф.Яхин

3) Үсемлексез, берни үсмәгән хәлдә. *Такыр анда, улым, сыер түгел, сарык ашарлык та үлән калмаган.* М.Яһүдин

◊ **Такырга калу** *к.* **такыр калу**. **Такыр калу** 1) Бөтенләй бушап калу

(кесә, янчык тур.); бетү; түкәнү, таксу (запаслар тур.). *Такыр калды шул кесәләр, Анда җилләр исәләр.* Р.Низами; 2) Кысынкылыкка, кытлыкка калу; ярлылану, бөлү. **Такыр юл** Берәр максатка ирешүнең ансат юлы. *Тормышта теләгеңә ирешүнең такыр юлы булмый.* Г.Минский. *Кешеләргә чәчер өчен яз, алга барырга такыр юл кирәк.* Ә.Гаффар. *Тормыш такыр юл түгел, вакыт-вакыт анда сикәлтәләр дә очрап куя.* Ә.Хәсәнов

**ТАКЫРАЙТУ** *ф.* 1) Такыр итү, тыгызлап тигезләү. *Без бәләкәй чакта су буендагы үзәнлектә бер шайтан таягы да, бер төп кычыткан да үсмәде, көннәр буе уйнап, без такырайта идек аны.* И.Нәбиуллина

2) *күч.* Бик еш булу. *Отпуск бетәр алдыннан, шундый теләк һәм өмет белән, Нәҗәр үзе такырайткан таныш юллардан үз кыйбласына таба китте.* Ә.Баян. *Алар редакциягә юлны шактый такырайттылар.* Ф.Җамалетдинова

3) *к.* **такырлау** (*2 мәгъ.*)

**Такырайта башлау** Такырайтырга тотыну. *Октябрь бәйрәме узгач, Габсаттар, фронтка китү ниятеннән, военкомат белән авыл арасындагы юлны такырайта башлагач, Әсмагөл йөрәгендәге ул шырпының кадавына чыдар әмәлләр бетте.* Б.Камалов

**Такырайта тору** Әлегә такырайту

**Такырайта төшү** Тагын бераз такырайту

**Такырайтып бетерү** Тәмам такырайту. *Гитлерчылар инде, сугышның беренче айларындагыча, 157 совет авиациясен тар-мар иттек, дип шапырынмыйлар, киресенчә, үзләре бункер юлын такырайтып бетерде.* Г.Әпсәләмов. *Бер көнне Мәскәү белән ике арадагы юлны такырайтып бетергән илчесе Аппак морзаны янына дәшеп алды [ул].* В.Имамов

**Такырайтып тору** Даими яки әледән-әле такырайту; әле, хәзерге вакытта такырайту

**ТАКЫРАЮ** *ф.* 1) Такыр булып калу, тапталып тигезләнү. *Юллар чатлап такырайды.* Р.Батулла

2) Чәч коелу, пеләшләнү. *Баш такыраю*

3) Берәр нәрсәнең өслеге ашалу. *Кайчандыр яхшы булып исәпләнгән пальтосының каракүл якасы инде такырайган, кесә тирәләре беләүләнеп ялтыраган.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Бушап калу, тотылып бетү. *Кесә тиз арада такырайды.* Г.Ибраһимов. *Кием-салым, ашау-эчү дип кайгырмыйсың, ләкин айдан айга кесә такырая иде.* С.Шәрипов. *Акча ягы такырайгач, кемнән әҗәткә сорап торыйм икән дип уйга калдым.* Бөгелмә авазы

5) *күч.* Начарлану, мөшкелләнү. *Ялгыз бер кешенең кулына карап тора башлагач, болай да эшләр такырайды.* М.Галәү. *Тамак ягы да такырайды, элек әҗер-күчтәнәчләргә яши идем, хәзер коры пенсиягә калдым...* Г.Гыйльманов

**Такыраеп алу** Бераз такыраю. *Беразга юллар такыраеп ала*

**Такыраеп бару** Акрынлап такыраю. *Күренеп тора: эш рәтен белүче – газон нолёвка белән алган кебек такыраеп бара иде.* М.Мәһдиев

**Такыраеп бетү** Тәмам, бик нык такыраю. *Атлар хәтсез еракта иде: арканлаган җир такыраеп беткәнлектән, читкә тартыла-тартыла, казыкны суырып алып киткәннәр күрәсең.* М.Шабай. *Такыраеп беткән һәм караңгыда аксылланып торган сукмактан территориянең бер почмагыннан икенче почмагына атлый.* Х.Камалов

**Такыраеп килү** Акрынлап такыраю, бетүгә якынлашу. *Табакның төбе дә такыраеп килә икән менәтерәк.* А.Хәлим

**Такыраеп китү** Соңгы арада сизелерлек такыраю. *Ашаулар такыраеб-рак китте шул.* Г.Камал. *Тирә-юнебезне дошман урап алган, матди яктан өшәнгән илларда да сыгылып төшмәгән саф, нык, куәтле рухыбыз ничек болай такыраеп киткән?..* Казан утлары

**Такыраеп тору** Вакытлыча такыраю

**Такырая бару** Торган саен такыраю. *Ашарына, кияренә такырая барган саен кешеләр бер-берсенә ярдәмчелрәк, шәфкатьлерәк була барган.* К.Тимбикова. *Ә кесә төбе такырая бара.* Татарстан яшьләре

**Такырая башлау** Такыраюга таба бару. *Күңелемнән, менә бусы соңгысы, яңадан бу юлга бармыйм, дип ант итәм, тик кесә такырая башлауга, антым онытыла.* Ф.Яруллин. *Акча янчыгы соңгы арада такырая башлады, кәрәзле телефон аркылы иртән авылга чылтыратып, бу хакта хәбәр иттем.* Татарстан яшьләре

**Такырая төшү** Берникадәр такыраю. *Сәгыйть абзый такырая төшкән башын уч төбе белән сыпырды.* М.Хуҗин. *Баш түбәләре такырая төшкән кавалерлар берәм-берәм читкә тайпылырга мәҗбүр булды.* Р.Мөхәммәдиев

**ТАКЫРБАШ** *и. сөйл.* **1.** 1) Башын кырдырган кеше. *Беркөнне өч такырбаш кергән иде.* Н.Гыймматдинова

2) *күч.* Надан, гыйлеме-белеме сай кеше

3) Дөньяга карашлары расизмга корылган кеше; скинхед: *русчасы*: **бритоголовый**. *Такырбашлар оешып кеше кыйнап кына йөрмиләр.* Кәеф ничек?

**2.** *с. мәгъ.* Башы такыр булган. *Никита Туранин, хан җилкәсенә орынып, бөек кенәз әмерен җиткезде – юк, такырбаш татар ханы аягүрә торырга теләмәде.* Р.Батулла. *Чәч китәрүче кызларның холкын беләсез инде, алар такырбаш клиентларга сәлам дә бирмиләр.* К.Кәримов

**ТАКЫРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **такырлау**

2) Такырга әверелү. *Берничә көн эчендә юллар такырланды, төзелеш мәйданында тузан болытлары уйный башлады.* Р.Вәлиев

3) *күч.* Начарлану, саегу. *Иванның хәтере вакыты-вакыты белән шундый такырлана ки, үзенең күпме ашаганын, күпме эчкәнен дә белми башлый.* З.Мәхмүди

**Такырлана бару** Акрынлап такырлану. *«Яшеллеген җуйган асфальт кебек Такырлана бара күңелләр» шикелле мисаллар китереп сокланды [ул].* Кызыл таң

**Такырлана башлау** Такырланырга тотыну; такырлану билгеләре күренү. *– Уф, нишләтәсез сез мине, Гөлнур, – дип, ул, ак яулык чыгарып, инде такырлана башлаган маңгай өстен сөртте.* Г.Әпсәләмов. *Соңга таба ашау ягы да такырлана башлады карчыкның.* Безнең гәҗит

**Такырлана төшү** Бик аз күләмдә, сизелер-сизелмәс кенә такырлану. *Шомбайларның бераз Күзен ачыйм, Такырлана төшкән Акылларын бераз языйм да...* Ф.Яхин

**Такырланып бетү** Бик такырлану. *Ә анда, дистәләгән аяк таптаган, такырланып беткән көлсу туфракта, тереклек ияләре яшәү өчен тырмаша.* М.Маликова

**Такырланып җиту** Тиешле дәрәҗәдә такырлану. *Әле юл такырланып җитмәгән.* М.Гафури

**Такырланып килү** Соңгы арада такырлану. --- *Иң элек ашау ягын карарга кирәк икән, чөнки азык-төлек тирәсе такырланып килә иде.* Т.Нәбиуллин

**Такырланып күю** Кинәт такырлану. *Көннәрдән бер көнне ул бөтенләй такырланып та куйды.* С.Рафиков

**Такырланып тору** Даими яки әледән-әле такырлану; әле, хәзерге вакытта такырлану. *Далада такырланып торган юл чатына җиткәч, кул-аяклары артка каерып бәйләнгән, киемнәре ертылып, үзе канга батып беткән Габдрахманны ташлап калдырдылар да, бөтен гаскәр, көчле йодрык булып, тиз-тиз генә төньякка таба китеп юкка чыкты.* В.Имамов. *Юл гел такырланып тора.* Татарстан яшьләре

**ТАКЫРЛА́У** *ф.* 1) Такыр итү, такырайту. *Һәр бирмеш көндә йөреп, җылы табан асты белән шомартып такырламагач, чистартып себермәгәч, йорт-күраны чүп үләннәре, төрледән-төрле чәчәкләр басымчак итә.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Нәрсәне дә булса тәмам бетерү; сарыф итү

**Такырлап бетерү** Бик яхшы такырлау. *Бүреләр генә такырлап бетергән.* Ф.Шәфигуллин

**Такырлап тору** Даими, әледән-әле такырлау; әле, хәзерге вакытта такырлау

**Такырлый төшү** Бераз такырлау. *Юлны такырлый төшү*

**ТАКЫРЛЫК** *и.* 1) Такыр булу, тигезлек, тигезләнгәнлек (җир өслеге тур.). *Республика территориясе аша узучы 400 чакрымга сузылган М–7 (Мәскәү–Уфа) юлының такырлыгы ташка үлчим ---.* Ватаным Татарстан

2) Кулланылып бетү, сарыф ителү; бушлык. *Тик базарчы бабай, безнең кесәбез такырлыгын белептер инде, аларны акчага сатмый.* М.Хуҗин. *Ләкин мәсьәләнең бер кыен ягы гына аны борчый – кесәнең такырлыгы.* Р.Кәрами

3) Такыр җир, такыр урын. *Бараклар янындагы такырлыкта кичләрнең берендә бер төркем егетләр тәмәке тартып утырдылар.* М.Мәһдиев

**ТАКЫ́Р-ТОКЫР** *иярт.* Тигезсез каты юлдан барган арба тавышын белдерә

**ТАКЫ́Р-ТОКЫР ИТҮ** *ф.* Каты юлда такыр-токыр бару

**ТАКЫ́Р-ТОКЫР КИЛҮ** *ф.* *к.* **такыр-токыр итү**

**ТАКЫ́-ТОКЫ** *хәб. сүз. сөйл.* **1.** 1) Бик аз; җитәр-җитмәс. *Ашарга такы-токы: он кайтармыйлар, ярма югалды.* А.Гыйләҗев. *Саҗидәгә бигрәк тә авыр, чөнки әле аңа унөч яшь тә юк, буыннары ныгымаган, өс-башы юка, ашау такы-токы.* Ф.Бәйрәмова

2) Начар, тиешле дәрәҗәдә түгел. *Минем урысчам такы-токы.* Н.Фәттах. *Янына һичкем тукталмый, Көне буе торып та; Урысчасы такы-токы, Шуңа авыз йомык ла.* И.Диндаров

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик аз, җитәр-җитмәс булып. *Ләкин ашау ягы бик такы-токы булганлыктан, анда озак яту мөмкин булмаган.* М.Мәһдиев. *Фрау Эльза бер кешелек паёк алып туклана, шуңа үзенең «натураль» хуҗалыгы биргәнне дә китереп кушкач, ризыклары Азат белән икесенә такы-токырак булса да җитеп бара.* А.Тимергалин

2) Аз, тиешле дәрәҗәдә түгел. *Урысчаны да такы-токы гына беләм.* Ә.Айдар

3) Көчкә, очын-очка ялгап. *Такы-токы яшәү*

4) Өзек-өзек, ишетелер-ишетелмәс, аңлашылыр-аңлашылмас. *Бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, такы-токы нидер сөйләнәләр, ә Акъәби, ишектән күзен алмыйча, аларны көтеп ята.* Ә.Еники

**3.** *с. мәгъ.* 1) Аз, җитәр-җитмәс булган. *Хәер сорашып дигәндәй тапкан такы-токы ризыкны кемгә җиткерсеннәр.* Н.Әхмәдиев. *Үзебезгә дә такы-токы гына акылны, юк-бар фикерне, телдән телгә, китаптан китапка йөреп шомарып беткән, бәясе өч тиенлеккә әйләнгән сүзләребезне алтын бәясенә сатарга тырышабыз.* Р.Миңнуллин

2) Очын-очка ялгап яшәрлек кенә. *Кая ул: икебез эшләп алган акчадан ике энигә өлеш чыгаргач, фатир өчен түләгәч, керәчинен-утынын кайгырткач, ипи-тозлык кына, такы-токы тормыш алып барырлык кына кала.* К.Миңлебаев

**ТАКЫ́-ТОКЫЛАНУ** *ф.* Бик азаю, җитәр-җитмәс булып китү

**ТАКЫ́-ТОКЫЛЫК** *и.* Җитешмәүчәнлек, кысанлык. *Халык, бура төпләренең такы-токылыгын сизмәгәнгә салышып, Хөсәен абзыйны өй борынча кунакка йөртте.* Г.Мөхәммәтшин

**ТАКЫЯ** *и. гар. этн.* 1) Ташлар, тәңкәләр белән бизәлгән сай цилиндрсыман хатын-кызлар баш киеме. *Такыямның күрекле ташы зөбәрҗәт, Матур йөзгә килешә шул чибәр зат.* К.Тинчурин. *Хәтфә калфаклар, чигелгән кәләпүшләр, укалы такыялар – һәммәсе Казаннан килеп, Мәскәүдә сатыладыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Әбинең өстендә ала-кола бикасап камзул, башында такыя, аның өстеннән юка шәл, баш түбәсендә кызыл ашъяулыкка төргән зур гына төенчегә бар.* Г.Бәширов

2) Түбәтәй, кәләпүш. *Бая һәм әйткән идек: кияү кыз катыннан бик яхшы такыя, күлмәк-ыштан, чикмән, сәгать алып кайта – кыз бүләге.* К.Насыйри. *Гади кәпәчен салдырып ыргыттылар да, аңа алтын ука белән чигелгән такыя кигезделәр.* Р.Батулла

3) Чәчәкләрдән үрелгән башка кия торган бөҗра. *Актан киенгәннәр, башларында кыр чәчәкләреннән үрелгән такыялар.* Г.Гобәй. *Юл буендагы әрәмәлеккә тукталып, җиләк тә ашадык, чәчәкләр җыеп, мин аңа такыя да үреп бирдем.* В.Нуруллин

**ТАКЫЯ-КАЛФАК** *и. җый.* Такыя һәм калфак ише баш киемнәре. *Борынгы чулпылар, тәңкәле хәситәләр, иңсәлекләр, такыя-калфаклар юкмы, дип сораша икән.* А.Тимергалин

**ТАЛ** *и.* **1.** 1) Талчалар семьялыгыннан гадәттә су буйларында куак булып үсә торган сомгыл чыбыклы, озынча

тар яфраклы агач. *Инеш хәзер үзе дә шул тал тирәли икегә бүленеп ага.* А.Хәсәнов. *Тал ботагында кычыткан чыпчыгы кыбырсына.* Ә.Гаффар. *Чишмә-инешләр типкән урыннарда сәрви, шомырт, камырлык, гөлҗимеш, тал, зирек агачлары, чикләвек куаклары тезелешеп утыра.* В.Имамов

2) *поэт.* Нәзек озын сабак. *Бакчада былбыл сайрыйдыр Баг гөлләре талында.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* Шул агач чыбыкларыннан үрелгән, шуннан ясалган. *Беришләре канау читләренә тал киртәләр кагалар.* М.Хәбибуллин. *Гаиләдә өченче кызы дөньяга килгәч, аның өчен тал бишек үргән эти.* Г.Сабитов

◊ **Тал чыбыгы ашату** Таяк яки чыбык белән кыйнау; җәзалау. *Халыкны тынычландырыр өчен, Казан губернаторы үзе авыл борынча халыкка тал чыбыгы ашатып йөрде.* М.Галәү. **Тал чыбыгы ашау** Кыйналу; җәзалану. *Тал чыбыгы ашап үскән малайлар ич, безгә күнегәсе түгел.* Р.Мөхәммәдиев. **Тал чыбыгыдай** *к.* **тал чыбыгы кебек**. *Безгә тал чыбыгыдай зифа буйлы бер кыз очрады.* А.Шамов. *Тал чыбыгыдай нечкә билле, зифа буйлы, озынча чибәр йөзле элекке Гөлүсәгә тамчы да охшамаган иде ул.* В.Нуруллин. **Тал чыбыгы кебек (сыман, шикелле)** Бик зифа буйлы, матур гәүдәле (хатын-кыз тур.). *Ул тал чыбыгы сыман зифа, күзләре зур, бит урталары алсуланып тора: тагы да матураеп киткән.* Р.Мөхәммәдиев

**ТАЛАЙ** *рәв. диал.* Күп кенә; шактый, байтак. *Талай кеше җыелды*

**ТАЛАК** I *и.* Умырткалыларда иммунитет тәэмин итү, матдәләр алмашы, кан ясалышы кебек процессларда төп функцияне башкара торган әгъза. *Канәгатьнең тын юлларындагы һәр төктә теге баягы татлы, ашказанын әйләндерә-тулгандыра, талак бизләрен суыра, зиһенне томалый торган хыялый серле ис тагын да яңарып көчәйде.* А.Хәлим. *Бөер, бавыр, талак кебек нечкә әгъзаларның кая урнашканын белеп эш итәләр [алар].* Т.Галиуллин

◊ **Талак кабару** *к.* **талак ташу**. *Ачудан талагы кабарган Нәҗипнең бүген «зират», «үлем», «инфаркт» дигән сүзләргә һич исе китмәде ---.* А.Гыйләҗев. **Талак ташу** Бик нык ачу килү; ачуны тыя алмыйча, берәр нәрсә эшләү. *Кайтып ашарга-эчәргә дә бирми, бу Хәйрулланың да талагы ташты.* Ф.Хөсни. *Алай талагы ташса, әнә безнең Таңсылу белән таныштырырга иде үзен!* А.Гыйләҗев

**ТАЛАК** II *и. гар.* **1.** 1) Шәригать буенча аерылышу. --- *Никах, талак өйрәндем.* М.Гафури

2) «Талак» сүзен әйтеп, талакны игълан итү гамәле. *Бер дә ялган түгел: атна башында никах яңарта да атна ахырында талак белдерә, мал-мөлкәт бүлешә.* Ф.Баттал

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* Никахны бетерү, аерылу (хатынын аеручы әйтә торган сүз). *Миңа бу хатын миннән талак, талак, талак!* К.Камал. *Шушындый гаугадан соң тагын үкереп җибәрә Хәйбулла абзый: – Талак!* Ф.Баттал. *Тыңлагыз: Сәринәгә миннән талак, талак, талак!* Н.Фәттах

**ТАЛА́К ИТҮ** *ф.* Шәригатьчә хатын аеру. *Тик тор! Оятсыз, намуссыз. Әгәр сиңа шул кабахәт хатын кирәксә, мине шушы минутта талак ит ---.* Г.Тукай. *Кичермисең икән – синең эш, хәзер үк талак ит.* Н.Әхмәдиев

**ТАЛА́К КЫЛУ** *ф. к.* **талак итү**. *Тукта әле, мулла кем, ничә талак белән талак кылдың?* Г.Камал. *Кайсыдыр китапта укыганы бар аның: бер адәм, гомер иткән хатынын талак кылып, яшь кызга өйләнмәкче булган.* М.Маликова

**ТАЛАКЛА́У** I *ф.* Шәригать буенча хатын аеру, талак белдерү. *Шайхразый Мирвәлине чакыртты: «Сиңа ике генә юл: я уйнашчы өтегеңне бүген үк талаклап аерасың, я аның белән өйдән чыгып китәсең».* А.Гыйләҗев

**ТАЛАКЛА́У** II *ф. к.* **талаулау**

**Талаклап китү** Кинәт талаклау. *Ала биям талаклап-нитеп китсә, --- аннан соң сөйләмә инде.* Ф.Бурнаш

**Талаклап тору** Әле, хәзерге вакытта талаклау; әледән-әле талаклау

**ТАЛА́К ХАТЫ** *и.* Хатынга талак ителгәнлек турында бирелгән таныклык. *Зинһар, миңа талак хаты бирсәнә; мин үз көнемне үзем күрер идем.* Г.Газиз. *Аның артыннан ук талак хаты килде.* Р.Батулла

**ТАЛАН** *и. диал.* Очраклы уңыш, табыш, бәхет. *Ялан-илан ни талан?* Әйтем

**ТАЛАНТ** *и. гр.* 1) Сәләт. *Шуңа күрә мин әйтәм: нигә сиңа үзеңнең талантыңны ул сыкрануларга әрәм итмичә, халыкка кирәкле эшкә файдаланмаска?* Г.Бәширов. *Талант – безгә Ходай бүләгедер, Ә осталык – ансы үзеңнән.* Н.Әхмәдиев

2) *сөйл.* Аерым бер шөгыльгә осталык, тәҗрибәлелек. *Мулла сүзне үзенең ат тану хакындагы талантына күчерә.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Зур сәләткә ия шәхес. *Бу шартлар --- меңнәрчә талантларның үсеп чыгуына юл ачты.* М.Җәлил. *Чын талантлар бер-берсен кабатламаска тиешләр.* Н.Фәттах. *Кабатланмас зур талантлар арабыздан китте.* Р.Фәйзуллин

**ТАЛАНТЛЫ** *с.* **1.** 1) Таланты (*1 мәгъ.*) булган. *Талантлы драматург Н.Исәнбәт гаҗәп оста сюжет бәйләнешләре, үткен, тапкыр сүзләр таба*... М.Җәлил. *Талантлы шагыйрьләр җитәрлек, талантлы укучылар аз*... Р.Миңнуллин

2) Таланты, осталыгы күренеп торган. *М.Гафуриның талантлы иҗаты миңа шул катлаулы тарихи чорларны үзенчә чагылдырган.* М.Җәлил. *Киндерләрне барлаган чагында, мин талантлы картиналарга юлыктым.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Оста итеп. *Җыентык авторының хикәяләре талантлы язылганнар, художестволы гадилек һәм эчкерсез сафлык күренеп тора.* М.Җәлил. *Язучыларның кайберләре талантлы әсәрләр яза, икенчеләре талантсыз әсәрләрен талантлы итеп мактата белә.* Р.Миңнуллин

**3.** *и. мәгъ. күпл.* Талантка ия кешеләр. *Гыйлем дөньясы талантлылар кулында булырга тиеш!* Ф.Яхин. *Ә талантлылар җитмәсә нишләргә?* Р.Вәлиев

**ТАЛАНТЛЫЛЫК** *и.* Талантлы булу сыйфаты; талант. *Кыскасы, чит телләрдә иҗат итеп дөньякүләм танылуга ирешкән милләттәшләребез үзләренең акыллылыгы, талантлылыгы белән беренче нәүбәттә татарга*

*бурычлы.* Р.Сафин. *Мондый мактауга алар зур тырышлык, талантлылык, осталыклары нәтиҗәсендә ирешкәннәр.* Гасырлар авазы

**ТАЛАНТСЫЗ** *с.* 1) Таланты бик аз булган яки бөтенләй булмаган. *Мин яза алмаслык, талантсыз кеше түгел.* Г.Бәширов. *Салыгыз хәбәр Хәбәрсез югалганнарга. Талантсыз, канатсызларга Бирегез янә дә канат!* Ф.Гыйззәтуллина

2) Таланты, осталыгы күренеп тормаган; каләм көче булмаган. *Әмма талантсыз әсәрләрнең язылмавы да кайчагында олы юаныч икән.* Р.Миңнуллин

**ТАЛАНТСЫЗЛЫК** *и.* Талантсыз булу сыйфаты; талант булмау. *Талант белән талантсызлык икесе ике якта...* Р.Зәйдулла

**ТАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **талау**. *Шәһәрләрең синең таландылар, Авылларың дөрләп яндылар...* Ә.Исхак. *Беттән таланып яшибез.* С.Поварисов

2) *күч.* Тузу, ерткаланып бетү (киемсалым тур.). *[Нургалинең] Өс-башы таланган, билгә кадәр кара сакал, яланбаш.* М.Мәһдиев

**Талана башлау** Таланырга тотыну. *Бары тик көндәгечә барлы-юклы калдык-постык ризыкларны ашаштырып, тамагын туйдыргандай иткәч, теләк тә, уй-фикерләр дә уянды, һәм тынгы белмәс яшь җан яңадан талана башлады.* Н.Фәттах

**Талана тору** Даими яки әледәнәле талану. *Сөннәр иленнән озатылган терлекләр, карабодай, тары кебек иң күп керем китергән затлы ярмалар, Кереш бугазына барып җитмичә, күпчелеге юлда талана торды.* Р.Сәгъди

**Талана төшү** Бераз талану

**Таланып бару** Өзлексез, бер-бер артлы талану

**Таланып бетү** Бик нык талану. *Шәмси белә иде инде: --- полк арыган, йончыган, иксез-чиксез походларда сугышчыларның өс-башлары, аяк киемнәре таланып беткән.* Г.Бәширов. *Башына таланып беткән колаксыз бүрек, өстенә инде күптән сәдәп күрмәгән кырык ямаулы бишмәт, аягына тишек чабата кигән.* З.Мәхмүди

**Таланып килү** Күптәннән бирле дәвамлы рәвештә талану. *Әлеге таш китаплар табылу, евроцентристлар тарафыннан фәндә хаксызга кыерсытылып, мирасы таланып килгән төрки халыкның рухи шәҗәрәсен бер башка биегәйтте.* М.Галиев

**Таланып тору** Даими яки әледәнәле талану; әле, хәзерге вакытта талану. *Ләкин Пальмира (анда искиткеч мәһабәт пальмалар үскән) даими рәвештә дошман гаскәрләре тарафыннан таланып торган.* М.Мәһдиев

**ТАЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **талау** I. *Этне эттән талаталар.* Мәкаль. *Анда безнең партизаннардан ике кешене, аягыннан асып, баганага элгәннәр дә тере көе овчаркаларга талатканнар.* М.Мәһдиев

**Талатып бетерү** Бик нык талату

**Талатып тору** Даими, торган саен талату, әле, хәзер талату. *Нәрсәгә шул кабыксыз бәрәңгедән (Сәхи Гөлзәриягә ни өчендер «кабыксыз бәрәңге» дип исем такты, бәлки, күлмәге ак булгангадыр) үзеңне талатып торасың?* Ф.Яруллин. *Әтәчкә дә талатып torгач, нинди хезмәтче буласың суң син?* Х.Ибраһим

**Талатып яту** *сөйл. к.* **талатып тору**. *Расхутыннан тормыйк, эзләтик барон братыбызны, безнең эше туганнарын демократлардан талатып ятмасын монда ---.* К.Кәримов

**ТАЛА́У** I *ф.* 1) Һөҗүм итеп, тешләр, тырнаклар белән йолыккалау, тешләп өзгәләү, чуку. *Эт талап, өсләргә таш яуганда да, Тартылып, хәлләр китеп ауганда да, сакладым бәгърем кисәгең җан кебек, Кан тамызмадым йөзеннән шунда да.* Ф.Бурнаш. *Мин фил инде, фил, ә бит мине кырмыскалар талый.* Н.Гыйматдинова. *Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер, сымаграк булып чыкты бу.* Г.Бәйрәмова

2) Күп булып тешләп, канны эчеп борчу (кандала, черки, бет һ.б.ш. бөҗәкләр тур.). *Черки талый кичләрен*

3) Кемнең дә булса милкен, малмөлкәтен көч кулланып тартып алу, маһирлык белән үзләштерү. *[Рабига]: Бая берсе яулыгымны тартып алган иде, инде шәлемне таладылар.* М.Фәйзи. *Бүләкне теләүчеләр бар, талап алучылар бар, списке буенча алучылар бар, ялындырып алучылары да бар әле.* Т.Миңнуллин

4) Дәрәҗә, хакимлек ярдәмендә башкалар хакын үзләштерү. *Алпавытка каян килгән соң мең десятина җир? Безнең нәсел-нәсәпне талап җыйган байлык бит ул.* К.Нәҗми. *Ә син монда гомер буена кешеләрне талап, үзеңә гөлбакча төзедең.* В.Имамов

5) *күч.* Бәясен чамадан тыш арттырып сату яки бик төшертеп сатып алу. *Сәүдәгәрләр план корып ята таларга, Күршедәге эшче кибетләре Үлем маршы җырлый аларга.* Һ.Такташ

6) *күч.* Түбәнсетеп, әрләп, рәнҗетеп тору. *– Әрәмтамак син, юкка ашап ятасың, – дип һаман әрли, талый икән.* Г.Ибраһимов. *Төнлә хатын талый бит, ди.* Х.Камалов. *Чөнки җиңелсә, гарьлегеннән шулхәтле үзен үзе талый, өзгәләнә, хәтта күзгә күренеп суырылып китә, ябыга иде.* М.Маликова

7) *күч.* Рухи газап китерү, борчу, тынгысызлап тору. *Рәхимсез мәхәббәт аның йөрәген элеккедән битәр талый.* И.Гази. *[Миңнеханның] Эчтә җанбәгырен ниндидер ут талый, тынгысызлый иде ахры.* В.Имамов. *Гаделсезлек, эшләгән эшеңне күрмәү җанны талый.* Г.Галиева

8) *күч.* Яндыру, һәлак итү. *Йолкыййолкый талый ялкыннар Кара тәре таккан танкны.* Ф.Кәрим

9) *күч.* Бик нык авырту. *Инде икеөч ай буена тамагыннан бер ризык та үтми, яман шеш дигәне эчтән талый, хәзер бар көннәре түшәк өстендә уза икән...* В.Имамов. *Күпмедер вакыттан, күңеле болганып, эче талап авырткангa уянып китте [ул].* Э.Якупова

10) *күч.* Көчле исеп йолкып алу (җил тур.). *Урамга чыгар идең, карлы яңгыр коя, тәрәзәләр парланып томаланган, җил ян бакчадагы шомырт агачларының соңгы яфракларын талап улый.* И.Гыйләҗев

11) *күч.* Нәрсәне дә булса гадел булмаган юллар белән үзләштерү, үзенә алу. *Карт оста, --- агач-ташны аннан талап, моннан талап, өй салып йөри.* Х.Сарьян

12) *күч.* Булдыксыз юну, үтмәс балта белән юну. *Бүрәнәне талау*

**Талап бетерү** Бик нык талау. *Шулхәтле мәҗбүриләп, кан костырып төзелгән колхозлар инде беткән, талыйсы малны җитәкчеләр талап бетергән, һәм аның урынына фермер хуҗалыклары төзегәннәр.* Ф.Бәйрәмова. *Тау куенындагы чишмәләр кипкән, ерткыч җанварлар бөтен куй-сарык көтүләрен талап бетергән.* Г.Гыйльманов

**Талап йөрү** Әле, хәзер талау. *Ник татар башың белән кеше талап йөрисең?* Н.Гыйматдинова. *Юлбасар җил урман читендәге куакларның соңгы яфракларын талап йөри, игене урылган арыш кырындагы камылларда сызгыра.* Г.Сабитов

**Талап килү** Күптәннән бирле даими талау. – *Әнә әнкәң гомер буе мине талап килә! – диде әтисе, уенын-чынын бергә кушып.* В.Нуруллин. *Уйламыйча гына язгандыр, дип белмә тагын, анда әйтелгәннәр байтактан җанымны талап килә иде.* И.Гыйләҗев

**Талап кую** Кинәт талау. *Ничә ел көч түкте, эшләп тапкан акчасын компанияне үстерүгә сарыф итте, ә Рәйхан аны хыянәтчел рәвештә талап куйдымы?* З.Мурсиев

**Талап тору** Әледән-әле яки бертуктаусыз талау; әле, хәзер талау. *Ләкин Казан гына түгел, Мәскәү ягы да бик күп югалткандыр, өстәвенә чирмеш җайдаклары арткы яклап аларның олаулары белән атларын да талап тора икән ---.* В.Имамов. *Кечесе әллә кайларга Себерләргә китеп, айдан айга: «Мине куып чыгаргандай чыгарып җибәрдегез, кайтам да малны бүләм», – дип, җанын талап торды.* Ә.Хәсәнов

**Талап яту** *сөйл. к.* **талап тору**. *Шушы авыр заманда да авылдашларын талап яткан бит, хәерсез бәндә!* Ф.Баттал. *Әнә бернәрсә эшләми кеше талап яткан адәмнәр әллә ничә машина алды, әллә ничә йорт салды.* Р.Сәгъди

**Талый башлау** Таларга тотыну. *Аннары ул кибеттән кайтып барганда, ата каз талый башлагач, мин аны ындыр артына кадәр озатып та куйганым бар.* Г.Бәширов. *Хан булу сәгатеннән ул дәүләт казнасын, халыкны талый башлый.* Р.Батулла

**Талый тору** Бернигә карамый талау. *Әмма Елмаймас мирза халык нәфрәтен игътибарына да элми: көче җиткәннәрне талый тора, кыра тора.* Р.Батулла

**Талый төшү** Тагын да ныграк талау

**ТАЛА́У** II *и.* 1) Хайваннарның һөҗүм итеп, теш-тырнаклар белән йолыккалавы, тешләп өзгәләве, чукуы. *Урманнан төшкән азгын этләр талау аркасында, инде ничә кеше шифаханәгә эләккән, ди.* А.Хәсәнов

2) Бөҗәкләрнең, тешләп, канны эчүе. *Черкинең талавыннан бигрәк безелдәве яман, ди торган иде Гариф абзый.* С.Поварисов

3) Башка кешеләр милкен тартып алу, үзләштерү гамәле. *Бүтәнчә талаулары җитмәгән, инде сөйгән кызларыбызга кул сала башлаганнар икән.* М.Фәйзи. *Барлы-юклы малларын күмделәр, бишенче елдагы талаулар кешеләрнең күңелләрендә төзәлмәслек яра калдырган иде.* И.Гази. *Талау эшен неккә башкаралар ---.* Р.Әхмәтҗанов

4) *күч.* Бәясен чамадан тыш арттырып сату яки бик төшертеп сатып алу күренеше. *Сәүдә эше – талау, алдашу, күз буяу ул.* М.Хәсәнов

5) *күч.* Түбәнсетү, рәнҗетү; рухи газап. *Синең ваклыкларың, көндәлек талауларың булмаса, бәлки, яшәр дә идек.* Ә.Әминев

**ТАЛА́У** III *и.* Мал-туарның аякларына зыян килү белән характерлана торган авыру. *Башыңа сырхау тисә, малыңа талау тия.* Мәкаль

**ТАЛАУЛА́У** *ф.* 1) Талау (III) белән авыру. *Талаулаган тайдан биз.* Мәкаль

2) *күч. диал.* Авыртудан бик газаплану. *Габдулла агай --- берничә көн йөрәгә белән талаулап ятты.* Ф.Хөсни

**Талаулап алу** Бераз талаулау

**Талаулап тору** Даими яки әледәнәле талаулау; әле, хәзерге вакытта талаулау

**Талаулап яту** *сөйл. к.* **талаулап тору**

**ТАЛАУЛЫ** *с.* Талау авыруы белән авырый торган; еш кына аяктан язып авырый торган. *Талаулы ат иясенә яу.* Мәкаль

**ТАЛАУЧЫ** *и.* Таларга (I) гадәтләнгән, талый торган, талау белән шөгыльләнүче кеше. *Көн саен диярлек авылга талаучылар килә: икмәкләрне алалар, каршы торсаң, төрмә белән, атып үтерү белән куркыталар.* И.Гази. *Талаучының, башкисәрнең башын өзеп, Бар дөньясын тетәр, сүтәр, тузан итәр!* Ә.Ерикәй

**ТАЛАУЧЫЛ** *с.* Талауга корылган. *Талаучыл сәясәт*

**ТАЛАУЧЫЛЫК** *и.* Талау (I) күренеше. *Үтеп талаучылык вакыты, Изелгәнгә ирек килде.* М.Җәлил. *Ирсезатасыз калган хатын-кыз туганнарыбыз талаучылык белән тормыш итә.* Р.Сәгъди

**ТАЛАШ** *и.* Ызгыш, гауга, низаг. *Башта болар калада бик зур шау-шу күтәрделәр, мөселман агай-эне арасында әллә ничаклы сүз, талаш булды.* Г.Ибраһимов. *Җомгада булган талаш Габденнасыйрның рухын шактый төшерде һәм аның киләчәктә мәктәпне беркадәр рәткә салу, укыту эшләрен тәртипкә кую турындагы ышанычын җимерде.* М.Галәү

**ТАЛА́Ш-ҖӘНҖАЛ** *җый. и. к.* **талаш-ызгыш**. *[Шәкертләр:] – Бетмәс монда солтан Хәмит агентлары! – дип, зур талаш-җәнҗал куптардылар.* Г.Ибраһимов

**ТАЛА́Ш КЫЛУ** *ф. иск.* Талашу. – *Балалар, – диде, – ашыкмагыз, минем килүем дә шуның өчен: кара айгыр йорты гомер буенча симез найманнар белән талаш кылды, дошманнарыгыз күп, инде тагы яңа бер дошман арттыруда сак булыгыз, – диде [ул].* Г.Ибраһимов

**ТАЛА́Ш-КЫЧКЫРЫШ** *җый. и.* Ызгыш, талаш, гауга; шау-шулы бәхәс. *Миһранның ялгыз алкышлары, «дөрес», «дөрес» дип кычкырган тавышлары аңа каршы кузгалган талашкычкырыш эченә батты.* Г.Ибраһимов

**ТАЛАШЛЫ** *с.* 1) Талаш, кычкырыштан торган, талаш белән уза торган; бәхәсле. *Шулай кат-кат Давытны иртәгә булачак талашлы җыелышка чакырып, Җиһангир өенә юнәлде.* Г.Ибраһимов. *Шушы сөйләшүләрдән соң, инде без Рәүф белән Галиянең тынгысыз, талашлы һәм трагик бәйләнеш белән бетә торган, көрәшле семья тормышы алдына килеп басабыз.* Г.Нигъмәти

2) Талаша, талаштыра торган, талаш, бәхәс китереп чыгара торган. *Ике якның бу талашлы сүзе барып ишетелгәч, мәдрәсәне акча белән караучы Кадыйр бай әйткән, имеш: «Чыкмасалар, полиция ни өчен?»* Г.Ибраһимов

**ТАЛАШЛЫ́-ТАРТЫШЛЫ** *с.* Бик тә җәнҗаллы, низаглы, ызгышлы. *Талашлы-тартышлы вакыйга*

**ТАЛА́Ш-СУГЫШ** *җый. и.* Талашу һәм сугышулар. *Талаш-сугыш булмагач, миңа да кызык бетте, тизрәк базарга очтым.* Г.Ибраһимов. *Һәр кич саен ихаталар эчендә талаш-сугыш.* В.Имамов

**ТАЛАШСЫЗ** *с.* 1) Тыныч хәл ителә торган, талашу булмаган. *[Мөселманнар арасында] җан исәбе алу өчен, талашсыз юллар табарга [кирәк].* Х.Кәрим

2) Талашмый торган характерлы, тыныч табигатьле. *Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, кара эшкә гаҗәп батыр.* Г.Ибраһимов

**ТАЛАШСЫЗЛЫК** *и.* Үзара татулык, тынычлык

**ТАЛА́Ш-ТАРТЫШ** *җый. и.* Талашу һәм бәхәсләшүләр. *Кайда булса да байлар белән хезмәтчеләр арасында талаш-тартыш чыкканлыгы турында сүз ишетелсә, ананың барлык тынычлыгы югала, йөрәген курку ала ---.* Г.Ибраһимов. *Менә шундый талаш-тартыш вакытына туры килдем мин.* Ә.Еники

**ТАЛА́Ш-ТИРГӘШ** *җый. и.* 1) *к.* **талаш-тартыш**

2) Кемне дә булса хурлау, әрләү. *Талаш-тиргәш ишетү*

**ТАЛАШТЫРУ** 1) *йөкл. юн. к.* **талашу**. *Юклык талаштыра, барлык яраштыра.* Мәкаль

2) Махсус рәвештә араны бозу. *Алар моны тик бер максат: әсирләрне үзара талаштырып, бер-берсен сатарга мәҗбүр итү нияте белән эшлиләр.* Р.Мостафин. *Ярыша-ярыша чәкән кимереп, тыныч кына яшәп ятканда, ирләр белән хатыннарны, егетләр белән кызларны талаштыра торган бер чир таралды.* К.Кәримов

**Талаштыра башлау** Талаштырырга тотыну

**Талаштыра бирү** Бернигә карамый талаштыру

**Талаштыра төшү** Бераз талаштыру

**Талаштырып бетерү** Бик каты талаштыру. *Хисләрнең дулкынланып торуын әдәби әсәрдә сурәтләү өчен, берничә алым бар: геройларның хәрәкәтләрен каршылыклы һәм кискен үзгәрешле, хәтта мантыйкка каршылыклы итәсең, сүзләрен киреләнүгә-үзсүзлелеккә корасың, һәммәләрне талаштырып бетерәсең.* Ф.Яруллин

**Талаштырып йөрү** *к.* **талаштырып тору**

**Талаштырып килү** Даими рәвештә күптәннән бирле талаштыру. *Байлык ул – гомер бакый адәм баласын шаштырып та, талаштырып та килгән нәрсә.* Кызыл таң

**Талаштырып тору** Даими, әледән-әле талаштыру; әле, хәзерге вакытта талаштыру. *– Без аларны гел шулай талаштырып торырбыз! – дип ырлаганнар яшь бүреләр, сөенешеп.* Р.Вәлиев

**Талаштырып чыгу** Барысын да бик нык талаштыру

**Талаштырып яту** *к.* **талаштырып тору**. *«Алып атам хәзер постны, кеше талаштырып ятасым килми», – диде ул.* Саба таңнары

**ТАЛАШУ** I *ф.* 1) Бер-берсен талау, тешләү (хайваннар тур.). *Этләр талашса – узгынчыга юл тыныч.* Мәкаль

2) Каты кычкырышу, ызгышу, тавыш чыгару. *Тик торганда талашмый җүнле кеше.* Г.Бәширов. *Хатын белән тәмләп талашабыз.* Н.Әхмәдиев

3) Бәхәскә керү, нәрсә өчен булса да көрәшү, даулашу. *Таңгатаров әллә кайчан ук шул әдәбият кичәсе ясау турында полицмейстердан рөхсәт ала алмый талашып йөри иде.* Г.Ибраһимов

**Талаша башлау** Талашырга тотыну. *Ибраһим ханның Нурсолтаннан туган угылы Мөхәммәт Әмин ханзадә белән һич тыныша алмый, алар тәхет өчен талаша башлыйлар.* Р.Батулла. *Сез, берегездән-берегез таза ирләр, шул хәерче берничә меңгә карап талаша башладыгыз.* Г.Каюмов

**Талашып алу** Берара бераз талашу. *Торганнарына ярты сәгать тә юк, әллә ничә тапкыр талашып алдылар.* Н.Әхмәдиев. *Бер-ике пассажир белән талашып алгач, ул Шәмси эскәмиясе янына килеп туктады.* Җ.Юныс

**Талашып бетү** Бик каты талашу. *Әнә милләтчеләр, уртак фикер эзләп, тыз-быз киләләр,ниләр генә кыйланмыйлар, үзара сугышып, талашып бетәләр.* Т.Галиуллин. *Узган ел без аның концертына барган идек, кайтканда, кызлар талашып беттеләр.* Р.Кәрами

**Талашып йөрү** Теләсә кайда, теләсә кайчан талашу. *Ояларыннан чыпчыкларны куып, сыерчыклар талашып йөри.* Г.Әпсәләмов. *Аның белән талашып йөрмә тагын, кеше көлдереп.* Г.Галиева

**Талашып китү** Кинәт талаша башлау. *Әмма көннәрдән бер көнне, хуҗасы белән хуҗабикәсе, берәүләрдән кунактан кайткач, бик нык талашып киттеләр.* А.Хәсәнов. *Шулай әйткәләшә торгач талашып ук китәләр.* К.Җәмит

**Талашып кую** Кинәт талашып алу. *– Әй, кичә талашып куйдык та, әйеме, әтисе! – дип, бүлмә яңгыратып көлеп җибәрде [ул].* Мәдәни җомга

**Талашып тору** Әледән-әле яки берөзлексез талашу; әле, хәзерге вакытта талашу. *Бер-ике хатын үзара гел талашып торалар.* Х.Камалов

**Талашып яту** *к.* **талашып тору**. *Төшлеккә теше тешкә тимичә туңып кайтса, ашарга пешмәгән, Һаҗәр белән әнисе пыр тузып талашып яталар.* Ф.Садриев. *Срам бит, җитмеш яшьлек анасы белән талашып ята икән, адәм хуры.* Ф.Баттал

**ТАЛАШУ** II *и.* Талаш, кычкырыш, ызгыш. *Ә японнар сабый чактан башлап тәрбияле, сабыр, алар үзара кычкырып талашуны белми.* В.Имамов. *Узган талашуларында Рәмилә иренә «райкомга барам» дип янады...* Ф.Садриев. *Көтмәгәндә бу чырылдау чәрелдәп талашуга әйләнеп китте.* Ф.Баттал

**ТАЛАШУ́-ЕЛАШУ** *ф.* Елыйелый кычкырышу; кычкырышу һәм елау. *Бигрәк тә җанга тигән тавышгауга юк, ә тегендә иртәме-кичме кемдер сөйли, көлә, талаша-елаша дигәндәй, ялгыз калуга бер минут та тәтеми.* К.Кара

**ТАЛАШУ́-ТАРТЫШУ** *ф.* 1) Каты бәхәсләшү, озак җәнҗаллашу; судлашу. *Инде талашып-тартышып торырга урын да юк иде шикелле.* И.Гази

2) *күч.* Көрәшү. *Көзге көн, җан биздергеч тормыш белән талашып-тартышып, илле ел гомер итте ул.* И.Гази

**ТАЛАШУЧАНЛЫК** *и.* Талашырга ярату сыйфаты. *Җыйган мәгълүматымда Зөһрә ханымның сугышчан, талашчанлыгы хакында бер сүз дә булмаганга, аның назик табигате пароходта да сугышып йөрү дәрәҗәсенә кадәр төшермәс иде дип ышанам.* Г.Исхакый

**ТАЛАШЧАН** *с.* Талашырга ярата торган, талашучан. *Талашчан кеше*

**ТАЛАШЧЫ** *и.* **1.** Талаш-ызгыш яратучы кеше; җәнҗалчы. *Сафура --- бөтен урамны берүзе шаулата торган усал талашчы булып җиткән.* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* Талашып яши торган, талаш чыгара торган. *Талашчы хатын этне туктатыр, үзе өрер.* Мәкаль

**ТАЛА́Ш-ЫЗГЫШ** *җый. и.* Һәртөрле талашлар, бәхәсләр, кычкырышулар. *Теләүче күп, талаш-ызгыш китте, чак сугышып та китмәдек, ләкин Таһирдан барыбыз да курка идек.* Ә.Еники. *Кая карама – очы-кырые күренмәгән чират, кая карама – талаш-ызгыш…* М.Хәсәнов

**ТАЛӘБӘ** *җый. и. гар. иск.* Укучылар, шәкертләр, студентлар. *Китапның язучысы Казандагы тиҗарәт мәктәбенең өченче сыйныф таләбәсеннән уналты-унҗиде яшьлек яшь бер шәкерттер.* Г.Камал. *Инсанга зарарлы булган эшләрдән, кабих гадәтләрдән ничек сакланырга, ничек итеп күркәм холыклы, әдәпле булырга юллар күрсәтеп, --- акчалар җыеп, фәкать таләбәләр яхут ятимханәләр файдасына тәгаен кылалар.* Ш.Мөхәммәдев

**ТАЛӘП** *и. гар.* 1) Катгый формада белдерелгән теләк. *«Эшчеләр үзләренең чамадан тыш таләпләре белән промышленностьны һәлакәт алдына куялар», – дип кычкыра фабрикантлар газетасы.* И.Гази. *Гаять дәрәҗәдә кыю таләпләр куеп, гарнизон солдатлары баш күтәргәннәр.* М.Хәсәнов. *Минем таләп шул: хәзер үк Алтынчәчне һәм аның иптәш кызларын ирекккә чыгарып, өйләренә озатыгыз!* А.Гадел

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса карата куелган, шуларга туры килергә тиешле шартлар җыелмасы. *Алкинда ачлыкка, кырык градус салкынга, хәрби таләпкә чыдамаган җаннар я аякларын туңдырып киттеләр, я качтылар.* С.Поварисов

3) Сорау, сорату (мәс., почтада). *Хатны таләп тәртибендә бирү*

4) Билгеле бер максат белән куелган тәртип, кагыйдә. *Шуңа күрә мин партком членнары бүген бу персональ эшне Устав куйган иң югары таләпләрдән чыгып тикшерерләр, дип уйлыйм.* Ф.Садриев. *Техника куркынычсызлыгы таләпләре, җиләк-җимеш, яшелчә, чәчүлек үстерү, хезмәт тәрбиясе бирү югары фәнни дәрәҗәдә дәлилләнә.* Р.Газиз

5) Ихтыяҗ, сорау. *Ләкин Американың бик еш мода алыштырырга яраткан хатын-кызларына мехның я ачыграк төслесе, я тоныграк төслесе кирәк була иде. Без, билгеле, бу таләпкә яраклашырга тиеш идек.* Ә.Еники

6) Берәр нәрсәне эшләүгә (мәс., бирүгә, алуга) рәсми язу; таләпнамә. *Шуңа күрә Совет Язучыларының Татарстан Союзы идарәсе, таләп рәвешендә, Сездән иптәш М.Галинең квартирын ары таба тыгызлауга юл калдырмавыгызны сорый.* Ф.Баттал

**ТАЛӘ́П ИТҮ** *ф.* Катгый итеп теләк белдерү; сорау. *Һәм ул сиңа, көненә мең аш төре таләп итсәң дә, китереп торачак.* Әкият. *– Мине беренче чиратта китәчәкләр исемлегенә керт! – дип таләп итә Соня.* А.Тимергалин. *Әмма Асия апа алардан утын таләп итми.* В.Нуруллин

**ТАЛӘП КЫЛУ** *ф. иск. к.* **таләп итү**

**ТАЛӘПЛЕ** *с.* Таләпләре катгый яисә бик югары булган. *Гаять җаваплы әсәрнең авторы, иҗат мәсьәләсендә аеруча таләпле Фатих Әмирхан белән артист иҗатын һәркемнән тирәнрәк аңлаган Кариев ни өчен тәҗрибәсез артисткага пьесаның иң әһәмиятле үзәк ролен бирергә булалар?* Ә.Еники

**ТАЛӘПНАМӘ** *и. гар.-фар.* 1) *к.* **таләп** (*6 мәгъ.*)

2) Берәр оешмага яки җитәкчегә нинди дә булса әйбер яки кешеләр сорап язган рәсми кәгазь; *русчасы:* **требование**. *Мең төрле таләпнамәләр язып, мәдрәсә башлыгының җанына тиячәк [ул].* С.Поварисов

3) Нинди дә булса мәгълүмат бирү, мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап язган рәсми язу; *русчасы:* **запрос**. *Депутат таләпнамәсе*

**ТАЛӘПСЕЗ** *рәв.* **1.** Таләп белдермичә. *Таләпсез бирелми торган хат*

**2.** *с. мәгъ.* Таләп итмәүчән. *Таләпсез түрә*

**ТАЛӘПЧӘН** *с.* **1.** 1) Югары, кискен таләпләр куючан, катгый таләпләр белдерүчән. *Төзелештә Гәрәй, Василий кебек яшь, энергияле, таләпчән, үткен күзле кешеләр кирәк иде.* А.Гыйләҗев. *Минем хатын ул яктан бик зәвыклы, таләпчән ул.* Ф.Баттал. *Аларның барысы да диярлек Зөфәр абыйның үткен күзләре, таләпчән сүзләре аша уза иде…* Р.Миңнуллин

2) Аерым шартларда гына яшәргә, үсәргә сәләтле булган. *Нарат --- табигать шартларына таләпчән түгел.* Робинзон эзләреннән

**2.** *рәв. мәгъ.* Югары таләпләр куеп, белдереп. *Мин ирем фикере белән килештем: әйе, Люция җитди, мәхәббәткә дә таләпчән карый.* М.Маликова. *Уен барышын, кагыйдәләр үтәлешен класс җитәкчесе булмаган укытучылар бик таләпчән хөкем итәчәкләр, имеш.* Р.Газиз

**ТАЛӘПЧӘНЛӘНҮ** *ф.* Таләпчән булып китү. *[Ул] усаллана, аның сүзе кинәт кенә катгыйлана, соң дәрәҗәдә таләпчәнләнә.* Казан утлары

**Таләпчәнләнә бару** Торган саен тагын да таләпчәнләнү

**Таләпчәнләнә төшү** Бераз таләпчәнләнү; тагын да таләпчәнләнү

**Таләпчәнләнеп бетү** Тәмам, бик нык таләпчәнләнү

**Таләпчәнләнеп китү** Кинәт таләпчәнләнү

**ТАЛӘПЧӘНЛЕК** *и.* Таләпчән булу сыйфаты. *Хөкүмәт газеталары эшчеләрне башбаштаклыкта, артык таләпчәнлектә һәм патриотлык юклыкта гаепли.* И.Гази. *Тормышка җитди каравы аның үз шәхесенә таләпчәнлегендә үк сизелә иде.* Ф.Яхин. *--- Һәр уңышның нигезендә таләпчәнлек, шәхси үрнәк, тырыш хезмәт ята.* Р.Газиз

**ТАЛӘПЧЕ** *и.* Рәсми язу белән нәрсә дә булса таләп итүче. *Таләпче мирасның бер өлешенә дәгъва итә*

**ТАЛГӨЛ** *и. бот. к.* **тал гөле**

**ТАЛ ГӨЛЕ** *и. бот.* Киндерчәләр семьялыгыннан хуш исле алсу катмар чәчәкле, тар яфраклы көньяк үсемлеге (урта киңлекләрдә бүлмә үсемлеге буларак та үстерелә); *русчасы*: **олеандр**. *Бүлмә өрәңгесенең --- чәчәкләре дә аның күңеленә хуш килмәде, ә менә тал гөлен ни өчендер яратты бәти.* Г.Мөхәммәтшин

**ТАЛГЫ** *и. диал.* Сусөярләр семьялыгыннан аякларында йөзү төкчәләре булган кара төстәге су коңгызы; сусөяр; *русчасы:* **жук-водолюб**

**ТАЛГЫН** *рәв.* **1.** 1) Йомшак кына, тигез һәм бер көйгә генә; салмак. *Шаулап торды шулчак талгын гына Ак каен да, имән, чаган да.* З.Мансуров

2) Ашыкмыйча, акрын гына, җай гына. *Ачык тәрәзәдән карыйм тышка, Талгын гына көзге таң ата.* Ф.Кәрим. *Җәйрәп яткан Идел кочагында Талгын гына йөзә пароход.* З.Мансуров. *Монда тормыш талгын гына, ашыкмыйча гына ага.* Н.Фәттах

3) Арыгандай авыр, салмак хәрәкәт белән. *Аннан талгын гына кузгала һәм кыйгачлап сөзәк юл ала...* Ф.Кәрим. *Каршы килгән машиналар әкрен килгән төсле тоелдылар, аның да һәр хәрәкәте талгын була башлады, башында чуалган уй-фикерләр кайдадыр таралып беттеләр, рәхәт битарафлык чолгап алды аны.* К.Кара

4) Соңга калып, көттереп кенә. *Елның салмак килүе, игеннәрнең талгын өлгерүе кохозчыларны ашыктырды.* Социалистик Татарстан

5) Тын, тыныч, җилсез (көн, һава, су һ.б.ш. тур.). *Идел өсте талгын, талгын, Әйләник әле тагын.* Ш.Маннур. *Кичә төне буе талгын гына яуган яңгырдан соң табигать үзе дә яңадан туган күк...* Г.Галиева. *Талгын гына җепшек кар ява.* Ф.Җамалетдинова

6) Сузып, сирәк-мирәк, ашыкмыйча. *Тын һавалы җәйнең кичендә Кошлар сайрый урман эчендә. Талгын гына күке моңлана ---.* Ф.Кәрим

7) Акрынлап, билгеле бер вакыт үткәч. *Авырту шулай эләктереп алды да талгын гына ычкындырды.* М.Кәбиров. *Хәбирәттәй, бөтен картлык тузаннарын берьюлы кагып төшергәндәй, рәхәт, тыныч, талгын йокыга талды.* Ф.Мөслимова

8) Җайлап, тавыш күтәрмичә. *– Ник кирәгегез чыккан аңа, нәрсә булган? – дип талгын, ипле генә сорашты ул.* В.Имамов. *– Тәүге чәйгә юри кешегә әйтмәдем, – дип, талгын гына сүз башлады каенанасы.* Т.Гарипова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Салмак, дулкын сыман; йомшак. *Күптәнме соң чәчәк атты шомырт, Талгын җилдә инде коела.* Ф.Кәрим

2) Акрын гына ага торган, тын. *Су өстеннән исә язгы җилләр, Тирбәлдереп талгын елганы.* Ә.Ерикәй. *Хан кызы талгын күлнең уртасына ук йөзеп керде.* В.Имамов. *Аның бәрхет тавышында кояшның сүнмәс яктысы, салават күперендәге барлык төсләр, елга-чишмәләрнең талгын челтерәве бар кебек.* Р.Низами

3) Салмак кына, тын гына ишетелә торган. *Күл өсте хәрәкәтләнә, чайкала башлады, ай да, агачлар да, ниндидер талгын көйгә биегәндәй, сырланып-киселеп хәрәкәтләнергә керештеләр.* Ф.Садриев. *Яхинның сихри көчкә ия булган, үзәккә үтеп керердәй моңсу, моңлы һәм талгын романсларын тыңлаган саен тыңлыйсы килә ---.* Шәһри Казан

4) Тымызык, тын, җилсез. *Талгын Идел өсте*

5) Салмак кына, җайлы, бер көйгә бара торган. *Бакча эшләреннән туктагач, тормыш тагын шул талгын агымына төште.* Ф.Яруллин

6) Уртача җылылыктагы. *--- Ләүкәдә чабынып, кайнарланган тәнеңә талгын су койсаң, күңелеңне борчыган уйларны да, юл газапларын да йөгерек көмеш су юып төшерә, яңадан тугандай буласың, рәхәтлек тә, бәхет тә хәттин аша!* Р.Хәбибуллина. *Куе ботка (абыста) пешкән кәстрүлнең өстен каплап, 20–25 минут талгын утта тоталар.* Т.Нәҗмиев

7) *диал.* Арыган, талчыккан. *Әле талгын чырай ялбырт итә, Әле көлгән чырай ялт итә.* Н.Исәнбәт

8) *диал.* Салкынча, җиләс. *Төнлеге ябылган, киезләре күтәрелгән --- бу тирмәләрдә һава бераз талгын иде.* Г.Ибраһимов. *Күләгәле, талгын урманнан Алмыш хан кояш яктысы белән тулы яланга килеп чыкты.* Н.Фәттах

**ТАЛГЫНЛАНДЫРУ** *ф.* Әкренәйтә төшү; баса төшү. *Мич утын талгынландыру*

**Талгынландыра төшү** Тагын бераз талгынландыру

**ТАЛГЫНЛАНУ** *ф.* 1) Талгын булып китү, акрынаю; салмакка әйләнү. *Әле кичә генә зәңгәрләнеп агып яткан елга, һавалар кинәт кенә суытып җибәргәнлектән, ашыга-ашыга көмешләнә, агымы талгынлана, авыраеп куера, шулай куера барып туңа да иде булса кирәк.* А.Хәлим

2) Тын булып калу. *Көне буе ике яктан да дәвам иткән каты атышлар басылган, һәм табигать, ничектер, тынып, талгынланып калган.* А.Шамов

3) Кызулык, эсселек кимү, сүрәнләнү. *Кояш түбәнәйгән, көн дә бераз талгынланган.* Г.Ибраһимов. *Мич авызыннан чыккан җылы өйнең каршы як стенасында талгынланырга --- да өлгерми, тәкәләр табагач һәм табаларның күңелле чылтыраган матур җырлары астында табын уртасына килеп тә кунаклыйлар.* Х.Мөдәррисова

**Талгынлана бару** Торган саен талгынлану. *Менә саз кылларыннан түгелгән аһәң талгынлана, җыру да салмаклана барып, чәчәннең мыек астыннан саркылган моңга әверелеп кала.* М.Галиев

**Талгынлана төшү** Берникадәр талгынлану

**Талгынланып китү** Кинәт талгынлану

**Талгынланып кую** Көтмәгәндә талгынлану

**Талгынланып тору** Вакытлыча талгынлану

**ТАЛГЫНЛАТУ** *ф.* 1) *к.* **талгынландыру**. *Салкынча һава йокыдан айнытып бетерә, яшел үләндәге чык, аяк киемен чылатып, тәнне талгынлата, сафландыра сыман.* Казан утлары

2) *з.-сыз* Талгын, таманча булып китү. *Кичкә талгынлатты*

**ТАЛГЫНЛА́У** *ф.* 1) *к.* **талгынландыру**

2) *сөйл. к.* **талгынлану**. *Тиз-тиз генә пәрдәләрне тарткалап куйды да су талгынлады.* М.Хәсәнов

**Талгынлап бетү** Бик нык талгынлау

**Талгынлап кую** Кинәт талгынлау

**Талгынлап тору** Даими яки әледән-әле талгынлау; әле, хәзерге вакытта талгынлау

**Талгынлый бару** Акрынлап талгынлау

**Талгынлый төшү** Берникадәр талгынлау

**ТАЛГЫНЛЫК** *и.* 1) Салмаклык, йомшаклык. *Гарифның Шәрәфи карт бүлмәсендә башлаган җыры да талгынлык, салмаклык белән ныграк тәэсир итә.* Р.Батулла

2) Акрынлык, түбән тизлек. *Елганың талгынлыгы*

3) Авырлык; арыганлык, талчыкканлык. *Хәрәкәтләрнең талгынлыгы*

4) Тик тору хәле, тынга калып тору. *Мәһабәт төз наратларның очлары ачык яшеллек белән яналар һәм, рәхәт бер талгынлыкка бирелеп, тик кенә торалар...* Ә.Еники

5) Җиләс, салкынча булу хәле. *[Ул] Мисырга шифалы дым һәм талгынлык алып килә.* Н.Фәттах. *Күктән талгынлык иңгән Казан киче.* М.Галиев

6) *күч.* Күңел тынычлыгы, хафасызлык, рәхәтлек. *Бөтен тәнемне ләззәтле бер талгынлык биләп ала да, мин ничектер бик тын гына, җайга гына, әйтеп бетермәстәй татлы рәхәт эченә күмелә башлыйм.* Г.Бәширов. *Күңелдә үзенә бер талгынлык, тәнне рәхәтләндереп, сәлперәйтеп куйган ялкаулык.* Т.Галиуллин

**ТАЛГЫ́НЧА** *рәв.* Үз көенә, җай гына, салмак кына. *Ике авыл арасында Елга ага талгынча.* С.Сөләйманова

**ТАЛДЫРГЫЧ** *с.* **1.** 1) Талдыра, ардыра, ялыктыра торган. *Күңел талдыргыч борчулар*

2) *сөйл.* Тынычландыргыч; йоклаткыч. *Талдыргыч дару*

**2.** *и. мәгъ.* Транквилизатор, психологик киеренкелекне бетерә торган дару

**ТАЛДЫРУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **талу**. *Салмак кына дөпелдәгән тукмак тавышлары картларны йокыга талдыра, яшьләр йөрәгендә тынгысыз дәрт кузгата.* М.Галәү. *Бар тарафны йокыга талдыргандай тын иткән.* Н.Хәсәнов

2) Арыту, ардыру, талчыктыру. *Әрем сабакларына, әрекмән яфракларына текәлеп юкка гына күз талдырдылар – сандугач күренмәде.* А.Гыйләҗев. *Ризык эзләп йөрмәс өчен каңгырып, Арлы-бирле чабып, тәпи талдырып, Соңгы тапкыр көз кояшы баюга, Кирәк булмас ятып йоклау Аюга.* Ж.Дәрзаман

**Талдыра башлау** Талдырырга тотыну

**Талдыра төшү** Бераз талдыру

**Талдырып бетерү** Бик талдыру. – *Әнием дә мине эзли-эзли аякларын талдырып бетергәндер, – дип шыңшый ук башлаган.* Көмеш кыңгырау

**Талдырып җибәрү** Кинәт талдыру

**Талдырып тору** Әледән-әле талдыру; әле, хәзер талдыру

**Талдырып яту** *сөйл. к.* **талдырып тору**

**ТА́ЛЕР** *и. нем.* XVI–XIX гасырларда Европада акча әйләнешендә мөһим урын тоткан, халыкара сәүдәдә озак вакытлар йөргән тәңкә. *Ул ишетә Судья өстәленә Талер чыңлап төшкән тавышны.* З.Мансур. *Мине аңларсыз дип ышанам һәм 100 талер акча сорыйм.* Кызыл таң

**ТАЛИБ** *и. гар.* 1) *к.* **талип**. *Ә һәрбер хөҗрәдә кырыгышар-иллешәр талиб бер дәрес укып тагать вә гыйбадәттә иделәр.* К.Насыйри. *Көллиятне – колледж дип, талиб һәм талибәләрне студентлар дип атасаң, дөресрәк булыр иде.* Р.Юсупов

2) *сәяси* Талибан тарафдары. *Талиб лидерлары даими рәвештә сорау алалар, хезмәттәшлек итәргә чакыралар.* Авыл таңнары

**ТАЛИБАН** *и. гар.* 1) Әфганстанда пуштуннар арасында барлыкка килгән, хәзер террористик агым дип кабул ителгән хәрәкәт. *Талибан даирәләре Русия хөкүмәтен чит ил эшләренә тыкшынуда гаеплиләр.* Р.Ибраһим

2) *ялг. к.* **талиб** (*2 мәгъ.*). *Тәмам азынган талибаннар ни кылмас?* Г.Гомәр

**ТАЛИБӘ** *и. гар.* Укучы кыз, студентка. *Бу кызлар, бу талибәләр кием калыплары булмыйча, бәлки --- энҗе вә алмазлардыр.* Р.Фәхретдинов. *Анда консерваториядә укучы талибәләр көч сынашты.* М.Әмирханов. *Я, әйт: кем мин сезнең яшь «даирә»гә? Исмем белгән һәр шәкерт, талибәгә?* Р.Гаташ

**ТАЛИГА** *и. гар. к.* **талигъ**. *Салган акчаларың аз булган, шулай да синең барлык бәхет, талигаләрең шунда язылган.* Г.Камал

**ТАЛИГАЛЫ** *с. иск. к.* **талигълы**. *Я рабби Ходаем, тәүфикълы, талигалы гомерләр насыйп ит.* Г.Камал

**ТАЛИГАСЫЗ** *с. иск. к.* **талигъсыз**. *Талигасыз икән башым: яшьтән күп михнәт күрдем.* Җыр

**ТАЛИГЪ** *и. гар. иск.* 1) Бәхет йолдызы; бәхетле йолдыз астында туу. *Бәхет булса, талигъ кирәкми; мәхәббәт булса, матурлык кирәкми.* Мәкаль

2) Бәхетле язмыш; бәхет-сәгадәт; эш уңучанлык. *Талигым, бәхетем минем һәр каралардан карадыр.* Г.Тукай

**ТАЛИГЪЛЫ** *с. иск.* Бәхетле йолдыз астында туган, сәгадәтле. *Мине тәүфикълы, талигълы бер егеткә бирәбез дип, Әхмәткә бирделәр!* Г.Камал

**ТАЛИГЪСЫЗ** *с. иск.* Бәхете булмаган, бәхетсез язмышлы

**ТАЛИП** *и. иск.* Шәкерт, укучы, студент. *Нәкъ төрек мәдәнияте белән кызыксынучы талиплар өчен «Төрекчә җәйге укулар» оештырылган да.* Өмет

**ТАЛИР** *и. нем.* 1) *к.* **талер**. *Унар талир, берәр кашимер күлмәк, пар читек-кәвеш бирерсең.* Т.Гыйззәт. *Шатлыгымнан, язган шәкерткә бер талир тәңкә бирдем.* Г.Исхакый

2) XVIII–XIX гасырларда күз төшкән кызга хисләрне белдереп җибәрелә торган көмеш тәңкә. *Бер кыз күрдем бик матур. Бирнә [бүләк] бирәм бер талир.* Җыр

**ТАЛИР ТӘҢКӘ** *и.* Талердан эшләнгән чулпы. *Талир тәңкәләрең чыңлаганда, Кем исменә җырлар җырладың.* Н.Исәнбәт. *Алып бирим талир тәңкә, так артыңа пар итеп; Ал кулыңа, сал куеныңа гомерлеккә яр итеп.* М.Фәйзи

**ТАЛКАН** *и.* 1) Кайнатып алганнан соң киптерелгән ашлыкның оны. *Юләргә талкан да бер, шалкан да бер.* Мәкаль. *Гөлниса апа баланың капчыгына азрак күмәч, бер шешә бал, бәләкәй янчык талкан --- һәм берничә*

*дәфтәр белән әле очламаган карандаш та куйды.* Г.Минский. *Гөлбануның да янчыгы бөтенләй буш йөрми: кипкән корт, эремчек, талкан, шомырт, чия, җиләк...* Т.Гарипова

2) Шул оннан кайнар суда болгатып әзерләнгән ашамлык. *Тиз генә талкан болгаттым, чәй кайнаттым, алдына ипи белән май куйдым.* Г.Бәширов. *Талканны бодай, карабодай, солы оннарыннан пешерәләр, һәм ул иң гади ашлардан санала.* Татар халык ашлары

◊ **Талкан итү** Бик каты сугып имгәтү; челпәрәмә китерү, юк итү. *Тик тор! Яңак сөякләреңне талкан итәрмен.* Г.Насрый. *Әйдә, биеп җибәрик, Бездә гайрәт җитәрлек; Безнең гайрәт тауны тузан, Ташны талкан итәрлек.* Ф.Яруллин. *Бомбалар җирне талкан иткәндәй дер селкетеп теткәләп китkәч, һөҗүмгә танклар күчте.* С.Поварисов. **Талканны коры тоту** Кырыс, усал булу. *Татар егете белән талканны коры тотарга кирәк: йомшак җәеп, катыга утырта, ягъни мәсәлән, инде пеләшләнеп килгән баш түбәңә ике яшьле мөгез куя күрмәсен!* Казан утлары. **Талкан талку** Бер үк сүзләр белән ачулану, орышу, тиргәү. *Анай карчык минем каршыма килә дә, чәчрәп-чәчрәп талкан талкый: телеңне йоттыңмы әллә, саламторхан, күзле багана.* Г.Әпсәләмов. **Талканы коры** Кырыс холыклы, усал кеше турында. *Ата кешенең талканы коры, күзенең агы белән генә карап, хатынының авызын бик тиз томалады.* М.Хәсәнов. *Миләүшә бу диңгезче егет алдында үзенең кинәт күндәмләнеп калуына аптырады. Ә бит шәһәрдән килгән бик кәттә егетләргә дә аның талканы коры иде.* Ф.Яруллин. *Талканы коры булуга карама, күңеле туры ул кешенең.* Р.Вәлиев

**ТАЛКАНЛЫК** *с.* **1.** Талканга яраклы булган. *Талканлык ярма*

**2.** *и. мәгъ.* Талканга яраклы әйбер. *Абзыйның талканлыклары бар икән.* Ф.Кәрим

**ТАЛКА́Н УТЫ** *и. биол.* Арчанчалар семьялыгыннан җепселләре күренеп торган ал чәчәкле, озынчарак яфраклы, күп ботаклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **толокнянка**. --- *Галл кислотасы арчанчалардан (вересковые) талкан уты (толокнянка) яфракларында 6 % ка кадәр булырга мөмкин.* Агулы үсемлекләр

**ТАЛКУ** *ф.* 1) Киндер, җитен кебек сүсле үсемлекләрнең сабагын уып, саламнан, кылчыгын сүстән аеру. *Гомере буе колхозда талкы талкыган, тары утаган, ясле балаларына аш пешергән, амбарда капчык ямаган Мәйсүфә ничек имансыз булсын?* М.Мәһдиев. *Ул үзен үбәргә дип омтылган йөнтәс аюның юылмаган озын сакалын ике яктан ике кулы белән җитен талкыгандай итеп тартты һәм, аны-моны уйламыйча, җан көче белән уң кулының сыртына тешләрен батырды.* А.Хәлим

2) Нәрсәне дә булса йомшарту, сүсләндерү. *Башаклар өлгергәч, аларны Талкыдым теткәләп-теткәләп.* Р.Харис

3) Нәрсәне дә булса уу, тетү. *Күпнең сүзе тимер талкый.* Мәкаль

4) *күч.* Бер үк нәрсәне кабатлау, гелгел искә төшереп тору. *Гәрәйнең исемен моңарчы да планёркаларда шактый талкыйлар иде, хәзер аны бөтенләй бетереп ташладылар.* А.Гыйләҗев. *Лейтенант, бер үк нәрсәне күпме талкырга мөмкин?* С.Шәрипов

5) *күч.* Борчып тору, эчтән ашау. *Мәрьямне газаплаган уйлар Шәукәтнең дә җанын талкый икән.* М.Маликова. *Бу сүз минем йөрәгемне, бавырымны, талагымны изә, талкый.* Н.Әхмәдиев. *Йосыф, башын талкыган сорауларга җавап табарга теләгәндәй, сикереп торып өенә ашыкты.* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Изү, арыту. *Юл арыта, талкый, ике көн буе каршыңда бер үк йөзләрне күреп, кемнәрнеңдер зар-моңын тыңлап бару туйдыра.* Р.Габделхакова

◊ **Талкып йон эрләү** Кемне дә булса теләгәнчә бик үзгәртү, теләгән кысага кертү. *Мин ашыгам. --- Бер сәгатьтән кайтам, аннан соң, теләсәң, мине талкып, миннән йон эрлә.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Талкый башлау** Талкырга тотыну. *Әлбәттә, фәнни дәрәҗәсе булмаган язучының исемле галимнәргә тибептибеп алуын бик күпләр гафу итмәделәр, «нигә безнең уҗымга кердең» дип, аспирантура баскычын үтмичә генә саллы фәнни хезмәт язган әдипне талкый башладылар.* М.Галиев

**Талкый тору** Бернигә карамый әледән-әле талку. *Үзем үләргә җитеп яраткан, җир йөзендәге иң-иң газиз кешемне әледән-әле талкый торам, әлләниләр уйлап чыгарам.* К.Миңлебаев

**Талкый төшү** Бераз талку

**Талкып алу** Бераз талку. *Аң бул, бюрода мин сиңа каты бәрелермен, нык кына талкып алырмын, яме?* Х.Камалов. *[Ул] шаулатып талкып ала ---.* М.Сәгъдиев

**Талкып бетерү** Тулысынча талку; бик нык талку. *Тикшерүче – ярым хәрби формадан киенгән, саргылт кыска чәчен артка яткырып тараган урта яшьләрдәге хатын – бик вакчыл һәм бәйләнчек булып чыкты, казынаказына нервыларны талкып бетерде.* С.Сабиров

**Талкып йөрү** Дәвамлы рәвештә талку; әле талку. *Нигә минем җанымны талкып йөрисез?* Ф.Яруллин

**Талкып килү** Электән талкып тору. *Күпме талкып киләм: һәр рота янында спорт мәйданчыгы, частьта стадион, хәрби каршылыклар полосасы булдырыйк, дим.* С.Шәрипов

**Талкып тору** Әледән-әле яки берөзлексез талку; әле, хәзерге вакытта талку. *Ничәмә-ничә еллар буена кызның гөнаһсыз күңелен талкып торган хәсрәт шәүләсе артка – калын пәрдә артына китеп барды шикелле.* К.Тимбикова. *Соңгы вакытта райком гел талкып тора үзен.* Г.Галиева

**Талкып чыгу** Тиз арада тулысынча талку. *Нәргиз «Лидо»га өйлә алдыннан гына килде, аңа кадәр банкта булырга, ресторанның узып барган елдагы финанс эшләрен тикшереп, талкып чыгарга өлгерде.* Р.Мирхәйдәров

**ТАЛКЫ** *и.* 1) Киндер, җитен ише сүсле үсемлекләрне талку җайланмасы. *Тыкыр-тыкыр талкыларың, җиңел йөри кулларың.* Җыр. *Аның ачыргаланып кычкыруын өзлексез шакы-шокы килеп торган талкы авазлары да баса алмады.* М.Хәсәнов

2) Талку эше. *Көзге талкы чагы, мунчаларда Кызлар җыелып җитен талкыйлар.* Ш.Маннур

3) Талкы өчен әзерләнгән һәм талкына торган сүсле үсемлекләр (киндер, җитен һ.б.ш). *Фонарь яна, Фонарь яктысында Кызлар бергә талкы талкыйлар.* Ш.Маннур. *Бөркәү астында кызларның өчесе дә, тезелешеп басып, талкы талкыйлар.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Әледән-әле ачуланып, тиргәп тору күренеше. *Үги анасының талкысы астында гына утыру аны бик туйдырган иде.* Ф.Хөсни

**ТАЛКЫЛЫК** *и.* Талкырга әзерләнгән җитен, киндер һ.б.ш.

**ТАЛКЫНУ** *ф.* 1) *тош. юн. к.* **талку**

2) *күч.* Аз гына нәтиҗәгә ирешү өчен дә бик күп көч сарыф итү, тырышлык кую; берәр нәрсә хәстәре белән җәфа чигү, артык көч кую. *Син дә менә --- әллә бөтен төшең җитү-түгәрәк булып, хозур кылу өчен генә шулкадәр талкындыңмы?* Р.Төхфәтуллин. *Эх, бигрәк таланды, талкынды шул авыл.* Г.Нурулла

**Талкына башлау** Талкынырга тотыну. *Тагын тирән уйларга, авыр кичерешләргә бирелә ул, тагын җаны туктаусыз изелә, талкына башлый.* М.Хәсәнов

**Талкынып бетү** Бик нык талкыну. *Мэлс болай да эш белән талкынып беткән…* Ф.Садриев

**Талкынып йөрү** Озак вакытлар талкыну. *Баксаң, болар инде ничә еллар буе талкынып йөргән бер үк уйлар, шул ук нәтиҗәләр икән!* М.Вәлиев

**Талкынып тору** Даими яки әледән-әле талкыну; әле, хәзерге вакытта талкыну

**ТАЛКЫШ** I *и.* 1) Сүсле үсемлекләрне талкудан соң калган салам яки вак чүбек. *Талкышны күпме талкысаң да талкыш булыр.* Мәкаль. *Шунда талкышлары коела, үзе йомшара.* Х.Камалов. *Камыш сабагы, салам, җитен талкышы да чимал булып хезмәт итә.* Төзү материаллары

2) Төтәсләгәндә күректә яндырыла торган чүбек. *Ул инде талкышына ут кабызган, ачкыч тишегән ача да әчкә күрек белә төтен өрдерә башлый.* Н.Исәнбәт

3) Талку җайланмасы. *Кул талкышында талкып, сүсне колхозга тапшырасың.* М.Әмирханов

**ТАЛКЫШ** II *и.* Әлбәне бал һәм шикәр комы белән татландырып ясалган һәм җепсел-җепсел булып торган, гадәттә конуссыман формадагы татлы ризык. *Кәләвәчеләр: «Монда чын сары майдан талкыш, абый, рәхим ит!» – дип кычкырынып утыра башладылар.* Г.Газиз

**ТАЛКЫШ КӘЛӘВӘ** *и. к.* **талкыш**. *Җырлы-биюле, милли киемнәргә мул сәхнәдән барган тамашаны татарның атаклы затлы ризыгы талкыш кәләвә тагын да миллирәк итте.* Ш.Баһаутдин. *Аш-су осталыкларын сынау өчен пешерелгән чәкчәк, өчпочмак, бәлеш, кош теле, талкыш кәләвә, тутырма, кыстыбый һәм гөбәдиянең уңганмы-юкмы икәнлеген барча тамашачы да сынап карады.* Ватаным Татарстан

**ТАЛКЫШЛЫ** *с.* 1) Талкышыннан арынып бетмәгән, арындырылмаган (сүс тур.). *Бер кочак талкышлы сүс күтәреп Заһит керә.* Ф.Хөсни. *Җеп эрләгәндә барлыкка килгән калдык исемнәре: чүбек яки пачас (рус. почёс) – Арчада һәм Кукмарада, бүтәкә – Мамадышта тәрәш тарагы артында калган талкышлы кыска сүсне белдерә.* Р.Рәхимова

2) *күч.* Борчулы. *Сәхнә – ул алкышлы да, талкышлы да ---.* Мәдәни җомга

**ТАЛКЫШСЫЗ** *с.* Талкышыннан яхшы арындырылган, әйбәт (сүс тур.).

**ТА́ЛЛАЙ** *ы. гар. сөйл. к.* **таллаһи**. *Лотфулла абый, җаныкаем, җибәр, валлай, билләй, таллай, икенче урламам, җибәр, дим.* Ә.Айдар

**ТА́ЛЛАҺИ** *ы. гар.* Үзе генә яки *валлаһи, билләһи* сүзләре белән кулланыла торган ант сүзе. *Валлаһи, таллаһи, кешегә әйтмәм.* К.Тинчурин

**ТАЛЛЫК** *и.* Таллар үскән урын. *Алдыбыздагы куе таллык аю йөргән кебек селкенә, ара-тирә калтырап чыккан тупас ирләр тавышы ишетелгәләп кала иде.* М.Әмир. *Яр кырыендагы таллыкларның яфракларында кояш нурлары селкенәләр.* К.Нәҗми

**ТАЛМА** *и. иск.* Вакыт-вакыт кузгала торган йөрәк чире. *Талымсызга – салма, талымлыга – талма.* Әйтем

**ТАЛМУД** *и. яһүд* 1) Яһүдиләрнең дин кануннарын эченә алган һәм шуларны аңлаткан изге китабы. *– Әткәй, – диде, – бәлки, син дә, әнә шул карт Исак Талмуд укып йөргән төсле, Коръән укый торгансыңдыр.* Ш.Камал. *Анда исә бу балалар Тора, Талмуд китапларыннан белем алганнар.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Сукырларча ышанып кабул ителә торган кануннар, кагыйдәләр турында. *Данияр хатын-кыз турында гына түгел, гомумән, күпчелек татар яшьләренең сукыр бер тиенгә тормаган талмуд чәйнәп чеп-чи надан булып калулары турында әрнеп, ачынып сөйли башлады.* М.Хәсәнов

**ТАЛОН** *и. фр.* 1) Транспортта йөрү, сатып алу, дәвалану һ.б.ш.ларга хокук бирә торган кечкенә билет, язу. *[Ак чәчле бер хатын-кыз] Буфетта ашарга талон бирде.* М.Мәһдиев. *Күренеп тора: иртә таңнан бүлнискә тешкә талон алырга ашыга бу.* Х.Мөдәррисова

2) Берәр документның аерып алырга мөмкин булган өлеше. *ГАИ инспекторы талонның гамәлдән чыккан икәнен сизмәгәнен шунда ук чамалап алдым.* Т.Нәҗмиев

**ТАЛОНЛЫ** *с.* 1) Талонга сатыла торган. *Талонлы продукт*

2) Талон системасы булган. *Үзәкне өзеп, талонлы, чиратлы совет дәвере искә төште.* Татарстан яшьләре. *Җиңел булмаган үзгәртеп кору елларында Анатолий намуслы хезмәт итү белән ярдәмче хуҗалык та тота, талонлы ул елларда бу зур ярдәм була.* Кама ягы

**ТАЛОНСЫЗ** *рәв.* Талоннан башка, талон булмаган көе. *Халык әсәренде: карточка системасы бетерелгән, кибеткә шикәр, прәннек, ара-тирә ипи кайткалый башлаган, укытучыларга, активистларга талон белән бирелгән чалбар, куртка, сөлге, мендәр тышы кебек әйберләрне теләгән кешегә талонсыз сата башлаган бер заман иде.* М.Мәһдиев. *Сохарины кибеттән талонсыз алырсың, мин кушты диярсең.* Г.Каюмов

**ТАЛПАН** *и.* 1) Хайван һәм кеше тәненә, шулай ук үсемлекләргә ябышып паразитлык итүче, гәүдәсе бербөтен яки ике өлешле, очлыкларында тырнак һәм имгечләре булган буынтыгаяклы хайван. *Талпан кадалган урынга йод сөртергә кирәк.* Ә.Халидов. *Талпан*

*тирене кимереп керә һәм анда күкәйләр сала.* Биология. *Бер үк вакытта күгәрченнәрнең бет, борча, талпан кебек паразитларны да таратуын онытмаска кирәк.* Шәһри Казан

2) *күч.* Башка берәү хисабына яшәүче кеше; паразит. *Сез – халыкны талаучылар, сез – халыкның бәдәненә кадалган талпаннар, кан эчүче кандалалар!* Р.Батулла

◊ **Талпан булып кадалу** 1) Нәрсәгә дә булса комсызланып ябышу; 2) Кемгә дә булса бәйләнү, каныгу. **Талпандай кадалу** *к.* **талпан булып кадалу**. --- *Сабир Зәйтүнә түтигә талпандай кадалды.* Р.Батулла. **Талпан урынына ябышу** *к.* **талпан булып кадалу**. *Ә киленнәр үзеңә талпан урынына ябышмыйча калмас, бигрәк тә Маһидәүрәне.* В.Имамов

**ТАЛПАННАР** *җый. и. күпл. зоол.* Үрмәкүчсыманнар классыннан гәүдәләре бербөтен яки ике өлешле, очлыклары тырнаклы һәм имгечле булган, ерткыч һәм үсемлекләрдә паразитлык итүче хайваннар төркеме. *Талпаннар арасында корткычлар һәм паразитлар күп, кайберләре кеше өчен куркыныч, чөнки төрле авырулар, мәсәлән, тимгелле тиф һәм кайтма тиф, нерв системасы авыруы – энцефалит күчерүчеләр булып торалар.* Биология. *Шул ук вакытта үләннең спирттагы төнәтмәсе кеше һәм хайваннарның тиреләре кычытканда, тире паразитларына – бетләргә, чәч ашаучыларга (волосоеды), борчаларга, талпаннарга каршы кулланыла.* Агулы үсемлекләр

**ТАЛПУ** *ф. диал.* Канат кагу, җилпү. *Чыгар-чыкмас канатларын талпып Очып киттең бала кош кебек ---.* Т.Гыйззәт

**ТАЛПЫНУ** *ф.* 1) Очып китәргә омтылып, канат кагу, җилпү; җилпенү. *Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...* Ә.Еники. *Җирдәге торна ишегалдын бетереп чабып йөри-йөри дә, җан-фәрманга талпынып, һавага күтәрелә.* А.Тимергалин

2) Билгеле бер юнәлештә очып китәргә яки очып килеп һөҗүм итәргә омтылып-омтылып кую. *Канатлары ныгый башлауга, кошчыклар да җилпенәләр, тар оядан иркен, очсыз-кырыйсыз күккә талпыналар.* И.Салахов

3) Бер урында канат җилпеп тору, очып йөрү. *Кызылармеецларның кайсыдыр авыз эченнән генә «Аерылышу» көен җырлый, һавада, я кинәт күтәрелеп китеп, я бер урында талпына-талпына, тургайлар сайрый, саф, ачык күк йөзендә кояш йөзә...* А.Шамов. *Юл буендагы эт эчәгенең кыңгырау чәчәкләре тирәсендә ак, сары, чуар күбәләкләр талпына.* Ә.Еники

4) Инерция белән бер яктан икенче якка тайпылу, янтаю, чайкалу. *Шаһвәли бер якка талпынып, Гәрәйнең беренче селтәнүеннән котыла да тәрәзәгә ташлана.* Г.Ибраһимов. *Өй эчендә, безнең баш очыбызда тармакланып сузылган, ниндидер үлән кушылган хуш исле тәмәке төтене талпынып йөзә башлады.* А.Шамов

5) *күч.* Бөтен көчне биреп тырышу, нәрсәгә дә булса бик нык омтылу. *Ләкин, ятып калганчы атып кал дип, тагын бер талпынасым килә.* Г.Ибраһимов. *Ул янә тибәргә талпынды.* В.Нуруллин

6) *күч.* Ниятләнү, теләү. *Чыңгыз, бу халәтеннән котылырга теләпме, үзе дә анык белмәстән, бүлмәдән чыгып китәргә дип, баскан урыныннан талпынган гына иде, аңа Камил тавышы ишетелеп киткәндәй булды.* Н.Хәсәнов. *Бөркет хакында Инсаф әллә ничә тапкыр әнисенә сөйләргә талпынды да, әмма үзенә генә билгеле серне чишүе, бөркетне күргән саен серле рәхәтлек тойгысы кичерүне югалтудан курыккан кебек эндәшмәде.* Т.Гарипова

7) *күч.* Күңел дәртләнеп, канатланып кую. *Кинәт күңелдә җылы, шатлыклы өмет чаткылары талпынып куйды.* А.Шамов. *Күңелләр нәкъ табигать кебек үк яңара, ашкынып талпына.* М.Маликова

**Талпына башлау** Талпынырга тотыну. *Шул уйлардан соң Нурулла канаты сынган кош шикелле талпына башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ул утырган җиреннән сикереп чыгардай иттереп талпына башлады.* К.Тимбикова

**Талпынып алу** Берара, бераз талпыну. *Әллә бер күрсәтеп кайтасы инде дип, талпынып та алды Асылхан.* М.Хәсәнов. *Сәетгалиев почмактан чыгарга итенеп талпынып алды ---.* Р.Мөхәммәдиев

**Талпынып җибәрү** Кинәт чак кына талпыну. *Өйрәткәнчә, Былбыл атның калку җилкәсенә тотынды, сул аягы белән Габделхәйнең уң кулына басты да бар көченә талпынып җибәрде.* Н.Фәттах

**Талпынып карау** Сынау өчен талпыну. *Килешүгә имзалар салганда, ул, Казанны бирмәс өчен, янә бер талпынып карады.* Р.Батулла. *Кемдер элекке урынына (чөнки унтугыз яшьтә нинди дә булса эш башкармаган егет-җилән юк иде инде) кайта, кемнеңдер бүтән һөнәр үзләштерәсе килә, икенче берәүләр укырга талпынып карамакчы.* Р.Кәрами

**Талпынып китү** Бераз талпыну. *Верещагин талпынып китте.* Г.Әпсәләмов. *[Кәримә] Җәһәт кенә талпынып китеп, тәрәзәгә ташланды, аны ачарга итте.* Ф.Яхин

**Талпынып кую** Кинәт талпынып алу. *Кинәт ул урыныннан ук талпынып куя, күзләре йомшак сагыш белән яктыра: «Минем дә әнием Әлкидән иде...»* М.Вәлиев. *Аны ишетеп, бар табигать талпынып куйды.* А.Мансуров

**Талпынып тору** Әледән-әле яки берөзлексез талпыну; әле, хәзер талпыну. *Ә шулай да әнием тире бушатырга гел талпынып тора иде, чөнки вагон бушатучылар рәтләп туналмаган сарык тиреләреннән май кырып алалар.* Т.Нурмөхәммәтов. *«[Кош] Әле һаман сумаладан ычкына алмый шулай талпынып тора икән», – дип, әкиятен тиз төгәлләп тә куя иде карт.* Ш.Шәйдуллин

**Талпынып яту** *сөйл. к.* **талпынып тору**. *Инде фани дөнья мәшәкатьләреннән бераз котылдым, хәзер үз уйларым, үз хыялларым белән иркендә яшәрмен, эшли башлаган эшләремне төгәлләрмен, рәхәтләнеп иҗат итәрмен, күңелдә талпынып яткан көйләрне язармын, дип кенә йөргәндә, канатларым янә салынып төште.* Р.Вәлиев

**ТАЛПЫНУЧАНЛЫК** *и.* Бөтен көчне биреп тырышу, омтылу сыйфаты,

үзенчәлеге. *Шуның белән бергә әсәрләрнең һәммәсендә дә булган тормыштан ризасызлык яки якты тормышка омтылучанлык, шуңа ашкынучанлык, шуны эзләргә талпынучанлык бар.* Г.Нигъмәти

**ТАЛПЫНЫШ** *и.* 1) Берәр якка ясалган кискен хәрәкәт, ыргылыш. *Күземдә соңгы яшь калды, Көчемдә – соңгы талпыныш.* Р.Гаташ

2) *күч.* Дәртләнеп, канатланып, бөтен күңелне биреп нәрсәгә дә булса керешү, алыну, омтылу. *Миңниса апа китәргә кузгалгач, миңа рәхмәтләр укыды, мин ул рәхмәтләрнең ни өчен икәнен аңламадым, күрәсең, малаен бәхетле итү өчен тагын бер талпыныш ясавы, эчен бушату мөмкинлеге бирүем өчендер дип кабул иттем мин бу рәхмәтләрне.* Ф.Садриев. *Кешедә эчке талпыныш, нәрсәгә дә булса омтылыш булырга тиеш.* Безнең гәҗит

**ТАЛТА** *и. тар. хәрби* 1) Тыл. *Талтада яшерен эш итү*

2) Дошманнан хәрби операцияне яшерү өчен куела торган отряд; һөҗүмнән саклану чарасы

3) Дәвалау чарасы, дару. *Сырхаудан талта табу*

4) *диал.* Юата, тынычландыра торган нәрсә, эш яки хәл; юаныч, юаткыч; мавыгу предметы. *Кайгыдан талта табу*

5) Иркәләп эндәшү сүзе. *Әнисә зирек һәм тал агачлары арасыннан килеп чыкты: – Ни бар, талтам? Нигә чакырдың мине?* З.Бәшири

**ТАЛТАЮ** *ф. диал.* Иркен, уңайсызланмыйча басып тору. *[Хаммат:] Качаммы соң! Торам шунда талтая басып. Беркая китмим.* Н.Исәнбәт

**ТАЛТИРӘК** *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан сулыклар буенда үсә торган очлаебрак торган яфраклы талга охшаш биек агач; *русчасы:* **ветла**. *Яр өстендәге куе талтирәк арасыннан гармун тавышы, кычкырып көлүләр ачык ишетелә, шау-шулы җанлылык көчәйгәннән-көчәя бара.* С.Сабиров. *Талтирәктә, чәбәләнә-чәбәләнә, былбыл елый.* Р.Батулла. *Бер урында чыршы-нарат үсә, икенчесендә – талтирәк дигәндәй...* Р.Мөхәммәдиев

**ТАЛ-ТИРӘК** *җый. и.* Талсыман агачлар, төрле тал агачлары. *Талтирәктә сайрый сандугачлар.* Ә.Ерикәй. *Ә буабызның файдасы сизелә дә башлады инде: су буендагы тал-тирәкләр яшәреп киттеләр, кипкән чишмәләрне тергезүче дә буа...* А.Тимергалин

**ТАЛУ** *ф.* 1) Озак һәм гел бертөрле хәрәкәтләр ясап эшләү, бер позада тору нәтиҗәсендә берәр әгъза ару, талчыгу. *Кулга тотыйм синең изге кулны – күп эш белән талган кулыңны.* М.Гали. *Тукай, чүгәләүдән аяклары талып, торып басты, оеган тез асларын ышкыды.* М.Хуҗин

2) Гомумән ару, бик нык йончу. *Дәресләрдән талу*

3) Тынычлык халәтендә булу, тынычлыкка бирелеп хәл җыю. *Сәлим бабай мич буенда ушада тик кенә талып утыра.* Н.Исәнбәт. *Бөтен буыннар талып кала, тар парта арасында тик утыруы шундый рәхәт...* М.Мәһдиев

4) Хәрәкәтләнмичә генә башкарыла торган шөгыльгә, халәткә бирелү. *Акрын гына бер моң сузылды да, Бөтен халык серле тынга талды шулай.* Ф.Бурнаш. *Сәлим яза торган шигыренә башын куеп, үзе дә сизмәстән, йокыга талды.* Г.Гобәй

5) *күч.* Гел бер төрле эш башкарудан ялыгу (күз, колак, баш мие һ.б. тур.). *Башы талган, йөрәге ара, хыял артык кызу эшли иде.* Г.Ибраһимов. *Карый-карый күзләрем тала, уйлый-уйлый зиһенем чуала.* Р.Кәрами

**Тала бару** Торган саен күбрәк талу. *Миңнур кичке тынлыкка һәм тынычлыкка тала барган урамга чыкты.* Г.Әпсәләмов

**Тала башлау** Талуга табан бару. *Бу эшкә Гамил белән Ядкарь бик теләп алынганнар иде дә, беләкләре тала башлагач, «диңгез бүреләре»нә дә чират белән кара эшкә җигелергә туры килде.* А.Тимергалин. *Китап укыйукый күзе тала башлагач, Айбиби ишегалдына чыкты ---.* М.Хәбибуллин

**Тала төшү** Бераз талу; тагы да ныграк талу. *Хәзер инде безнең беләкләр тагы да тала төшә, гел иелеп ишкәнлектән, бигрәк тә бил авырта, көймә төбендәге аркылы тактага терәгән аякларыбызга да көч килә ---.* Т.Нурмөхәммәтов

**Талып алу** Беразга гына талу. *Йокыга һәр талып алу (төшендем) Үлеп каравы икән шул кешенең.* Р.Харис

**Талып бару** Тулысынча талу халәтенә якынлашу. *Кичә кич ачык тәрәзә янында йокыга талып барганда, пристань ягыннан сезнең «Владимир Маяковский» пароходы тавышы ишетелгән кебек булды.* С.Сабиров

**Талып бетү** Бик нык талу. *Хатлар, портретлар актарып та күз талып беткән...* Г.Ибраһимов. *Алдыңа, тирәягыңа карый-карый, күзләрең талып бетә.* Н.Фәттах

**Талып китү** Кинәт талу. *Бераздан озак утырудан биле талып киттеме, зифа сынлы кыз кабинадан чыкты.* Р.Камал

**Талып тору** Әле, хәзер талу; вакытлыча талу

**ТАЛЧУК** *и. рус сөйл.* Иске-москы, вак-төяк әйберләр сатыла торган базар. *Тәмам бер талчук кибете ачарлык бар икән.* Г.Камал. *Бераздан мин талчукка җиттем.* Һ.Такташ. *– Алай булгач, әйдә, талчукка барып, ике йөз тәңкәсенә берәр әйбер карыйк! – дип, ул мине җәяүләп кенә бүтән базарга алып китте.* В.Нуруллин

**ТАЛЧУКЧЫ** *и. сөйл.* **1.** Талчукта сәүдә итүче вак сәүдәгәр; талчукта еш булучы кеше. *Монда борын-борыннан килә торган гадәтләрен саклаган талчукчылар очрый, буяу пумаласы, күзлек кысасы, самавыр трубасы, комган, ләгән ише нәрсәләр, башка йорт кирәкяраклары тезелеп тора.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Талчукта сәүдә итүче. *Карт үзенең кайчандыр Таибә абыстай кебек талчукчы хатыннарны чүпкә дә санамаган шәүкәтле чакларын исеннән чыгармый иде ---.* Ә.Еники

**ТАЛЧЫБЫК** *и.* 1) Озын, сыгылмалы, шома тал чыбыгы. *Байназарның кулында быелгы талчыбык иде, шуның яфракларын өзә.* М.Хуҗин. *Тормыш ул – талчыбыктан үрелгән каз оясы.* Н.Гыйматдинова

2) *бот.* Талчалар семьялыгыннан комсыл туфракларда яхшы үсә торган куак; *русчасы:* **шелюга**. *Талчыбыклар, шыбыр-шыбыр килеп, Бу матурга сәлам бирделәр.* М.Җәлил. *Нинди ямьле*

*Килә сыерчыклар, Бөреләнгән нечкә талчыбык.* Ә.Ерикәй

◊ **Талчыбык кебек** Зифа гәүдә турында. *Әминә талчыбык кебек нечкә, зифа буйлы.* Г.Әпсәләмов. *Кыз үтә дә чибәр, сөйкемле, талчыбык кебек зифа буйлы, нечкә билле иде.* З.Зәйнуллин

**ТАЛЧЫГУ** *ф.* 1) Тән, мускуллар бик ару, талу. *Авыру Илсөяр генә түгел, инде атлар да талчыктылар.* Г.Гобәй. *Талчыккан аякларны көч-хәл белән атлап, мышкылдап, чәнәшкәләребезне тау башына сөйрибез.* Г.Бәширов

2) Хәлсезләнү. *Ул, озак-озын походларда да арымаган егет, бүген бу унбиш чакрымлык юлдан арып, талчыгып, нервланып, ачуланып кайтты.* А.Шамов

**Талчыга бару** Вакыт үткән саен күбрәк талчыгу

**Талчыга башлау** Талчыгуга табан бару. *Яннарында бер икмәк сыныгы да юк иде, ярга чыгып, якындагы кибеттән күмәчләр алып килделәр, ачлыктан талчыга башлаган үрдәкләрне озаклап ашаттылар.* Г.Гыйльманов. *Әмма ук та мәңге оча алмый, күпмедер вакыт үткәч арый, талчыга башлый.* С.Шәмси

**Талчыга төшү** Бераз талчыгу. *Укучылар һәммәсе дә ябыга, талчыга төшкәннәр.* Г.Әпсәләмов. --- *Бу тантанадан шактый арый, талчыга төшкән зал гадәттәгечә иренеп кенә кул чабарга тотынды.* А.Хәлим

**Талчыгып бетү** Тәмам талчыгу. *Кыш буенча Мәскәүнең номер һавасында талчыгып беткән аның яшь, зифа әгъзаларына яңадан-яңа көч кергәндәй булды.* К.Тинчурин. *Эшлисе эшләр бик күп, анда утырып талчыгып кына бетәр.* Аманулла

**Талчыгып җитү** Бик талчыгу. *Арыдым, тирләп беттем, Тәмам талчыгып җиттем. Шулай итеп урманда Җәнлекләрне биеттем...* Р.Вәлиева

**Талчыгып китү** Кинәт талчыгу. *Талчыгып киткәндәй булды ул.* М.Маликова. *Сәгать унберенче киткәч, бик кызыклы фильм барганда, Рәхимҗан әйтә куйды: – Әллә нигә талчыгып киттем әле, Гөлсинә.* Р.Фәизов

**ТАЛЧЫККАНЛЫК** *и.* Талчыккан булу, талчыгып бетү халәте. *Хатынының ни дәрәҗәдә талчыкканлыгын башына китерә алмый ул, бичара.* Ә.Баян. *Ританың йөзендә талчыкканлык, арыганлык сизелә, күзләре сүнгән, бик ябык.* Х.Мөдәррисова

**ТАЛЧЫКТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **талчыгу**. *Күрәсең, көне буе авыр кием белән юлда йөрү аны шактый талчыктырган иде.* Ф.Садриев

2) *з.-сыз* Ару, талу. *Шактый талчыктырган иде инде.* А.Тимергалин

**Талчыктыра бару** Торган саен ныграк талчыктыру

**Талчыктыра башлау** Талчыктырырга тотыну

**Талчыктыра төшү** Бераз талчыктыру

**Талчыктырып бетерү** Бик каты талчыктыру

**Талчыктырып җибәрү** Кинәт кенә талчыктыру

**ТАЛЫГУ** *ф.* Ару, талчыгу; ял итәсе килү. *Я, орчыгың шаулавына Талыктыңмы, әткәем.* Дәрдемәнд. *Кул-аяк буыннарым талыгып, йомшап китте.* Г.Галиев. *Күп уку сәбәпле алар тиз арый, талыга.* Кәеф ничек?

**Талыга бару** Торган саен ныграк талыгу

**Талыга башлау** Талыгуга табан бару

**Талыга төшү** Бераз талыгу

**Талыгып бетү** Тәмам, бик нык талыгу

**Талыгып китү** Кинәт кенә, көтмәгәндә талыгу

**ТАЛЫМ** *и.* Ашамлыкка, аш-суга карата сайланучанлык, нәзбереклек, таләпчән булу. *Тәмлегә дә талым бар.* Әйтем. *Тамак дигәннән, тәмлегә талымым юк, тәмсезгә комсызлыгым юк.* Н.Кәримова

**ТАЛЫМЛА́У** *ф.* 1) Ризык сайлану, нәзбереклэнү. *Аннары, ярты гомерен тулай торакларда яшәп үткәргән (өч ел армия дә шул ук тулай торак инде, аталышы гына икенче: казарма) кеше ризык талымлыймы?!* Р.Кәрами

2) Билгеле бер ризык ашыйсы килү (авырлы хатын-кыз тур.). *Ә шул вакытта үзебезнең халык яшелчәгә тилмерә: хатыннарыбыз корсак күтәргәндә тозлы кәбестә талымласалар, ат җигеп, күрше авылларга чабабыз, балачагаларыбыз бер кыяр кабарга зар булып, караклыкка өйрәнәләр.* М.Әмир

3) *күч.* Сайлану, яхшыракны сайлап алырга омтылу. *Транспорт мәсьәләсенә килгәндә, талымламыйбыз, ни бирсәләр, шуңа ризабыз.* Т.Гарипова

**Талымлап алу** Берара талымлау

**Талымлап йөрү** *к.* **талымлап тору**. *Киленне әйтәм, җәйдән ук, тамагыннан үтмичә, ашау талымлап йөргәние, шикләнүем хак булган икән.* Г.Галиев

**Талымлап кую** Аз гына талымлап алу

**Талымлап тору** Даими яки әледәнәле талымлау; әле, хәзер талымлау. *Ир балалары бер ул гына булганга күрә, аңа эш талымлап торырга туры килмәде.* И.Гази. *Талымлап тора торган заман түгел хәзер!* В.Нуруллин. *Минем үземнең талымлап торган юк, ипи булса, лакан суын да эчеп бетерәм.* Ф.Садриев

**Талымлый башлау** Талымларга тотыну. *Алай дисәң, азык талымлый башлавыннан әнисе беренче айда ук сизенде: мичтә тәгәрәтеп пешергән бәрәңгене кабыгы-ние белән суганлап ашаганда, авыз читләренә су җыела, суганны да кисеп түгел, йодрыгы белән сытып ашый.* Р.Хәбибуллина

**Талымлый төшү** Бераз талымлау

**ТАЛЫМЛЫ** *с.* **1.** 1) Аш-су сайланучан, нәзберек; тәмлетамак. *Талымлы дуңгызны ашату кыен.* Әйтем. *Аннары бу яңа кунак үз-үзен тотышы белән дә тегеләрдән нык кына аерыла: мөгамәләсе һәрвакытта нәзакәтле, ә ашау-эчүгә килгәндә шактый талымлы, моны инде официантлар беренче нәүбәттә сизеп алалар.* Ә.Еники

2) Сыйга куела торган; бәйрәмчә, затлы аш итеп кабул ителгән (сый, аш тур.). *Франциядә укъяфрак бүлбеләрен күптәннән бирле талымлы азык итеп ашыйлар.* Робинзон эзләреннән

3) Сайланучан, таләпчән. *Талымлы кыз картаймас.* Мәкаль. *Ә рәссамнар – бик талымлы халык, аларны сирәк кеше рухландыра, ышанызгыз миңа.* М.Маликова. *Композиторга бер генә теләгем бар: текст авторларына талымлырак булырга иде.* Р.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* Аш-су сайланучан кеше, тәмлетамак. *Талымлыга аш килешми.* Мәкаль

**3.** *рәв. мәгъ.* Сайлап, таләпчән якын килеп. *Юк, ул күсәк күтәрми, сабыр-үтемле өслүб белән, яулап алынган түгел, ә өстән бирелгән сүз ирегеннән чама белеп файдалана, талымлы яза.* М.Галиев

**ТАЛЫМЛЫЛЫК** *и.* 1) Аш сайлаучанлык, талымлы булу. *Талымлылык егеткә туйда гына килешә.* Мәкаль. *[Аның] буй-сынының әле дә тал чыбыгы шикелле зифа саклануы, мөгаен, ашау-эчүгә талымлылыгы аркасындадыр.* М.Әмирханов

2) Таләпчәнлек. *Инде шагыйрьнең яңа әсәре – «Кавказ күренеше»нә кайтсак, анда да без шигъри сүзгә соң дәрәҗәдә талымлылык белән очрашырбыз.* Р.Мөхәммәдиев

**ТАЛЫМСАК** *с.* Бик талымлы, артык талымлый торган. *Бәбиле хатын талымсак булыр.* Әйтем

**ТАЛЫМСАКЛАНУ** *ф.* Талымсак булып китү, нәзберекләнү

**ТАЛЫМСЫЗ** *с.* 1) Аш-суны сайламый торган, нәзберек булмаган. *Ашауга талымсыз бу ирләр.* Г.Гыйльманов. *Бигрәк талымсыз кешеләр, көненә ике генә ашыйлар.* С.Шәрипов. *Катык, әйрән дигән нәрсәгә бик тә талымсыз, комсыз иде шул ул.* А.Хәлим

2) *күч.* Сайланмый торган. *Моңарчы урманда эшләү, фин кампаниясе вакытында колакларын йомып утырмау, ниһаять, табигый зирәк акылы, кыю, батыр йөрәге, талымсыз холкы аңа бик нык ярдәм итте.* Г.Әпсәләмов. *Чиртми колач буе балыклар, хәтта талымсыз ташбаш та әләкми.* М.Хуҗин. *Гаилә корганда җавапсыз һәм талымсыз булма.* Т.Миңнуллин

3) *күч.* Күндәм, карусыз, кире какмый торган, теләп, яратып эшли торган. *Эшкә талымсыз Гөлмәрфуга суга көненә ике-өч барып кайта.* З.Мәхмүди

4) *күч.* Әрсез, принципсыз. *Талымсыз кунак такка калдырыр.* Мәкаль. *Сибгат аганың бу сүзләре, жанрдан жанрга күчеп, бер жанрда да юньле шигырьләр яза алмаган кайбер талымсыз шагыйрьләргә киная рәвешендә әйтелде.* Г.Рәхим

5) *күч.* Чыдам, кырыс шартларга бирешмәүчән; әрсез. *Алар тирәсендә йөкләрен бушатуны көтеп торучы, һәркайсы өстенә бизәкле итеп, үзләре бәйләп, йон фуфайка яисә сугыш вакытының иң әрсез һәм талымсыз киеме – яшел тәнҗылыткычлары кигән кызлар, киленнәр Нәфисәнең Хәйдәр белән берүзе узып баруын елмаешып карап калалар.* Г.Бәширов. *Җир резина түгел: киңәйми, берни үсми торган вак ташлы бернечә карыш җирләргә, ашлама кертеп, талымсыз иген сорты чәчергә туры килә.* Х.Камалов

**ТАЛЫМСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Талымламый торган булып китү

2) *күч.* Комсызлану; чаманы югалту. *Югыйсә мин генә талымсызланган булып чыгам.* Ә.Гаффар. *Мин нык баеп китәргә җай чыккан чорларны да кичердем, әмма, талымсызланып, байлыкка кызыкмадым, Аллаһыдан курыктым.* М.Галиев

**Талымсызлана бару** Торган саен күбрәк талымсызлану

**Талымсызлана башлау** Талымсызлануга табан үзгәрү

**Талымсызлана төшү** Бераз талымсызлану. *Сәфәремнең шушы бушлыкка охшап калмавын тели иде күңел, талымсызлана төшеп, күргән-ишеткәннәрне хәтер сандыгына тутыра башладым.* Ф.Сафин

**Талымсызланып алу** Азрак талымсызлану. *Атлар талымсызланып алалар, күчәрбашлар, аларны тыя төшеп, дилбегәләрен тартып куялар.* М.Хәбибуллин

**Талымсызланып бетү** Бик талымсызлану

**Талымсызланып китү** Кинәт талымсызлану. *[Кош] Тора-бара әрсезләнеп, талымсызланып китте.* Ә.Моталлапов

**ТАЛЫМСЫЗЛА́У** *ф. сөйл. к.* **талымсызлану**

**ТАЛЫМСЫЗЛЫК** *и.* 1) Талымсыз булу, ашны сайлап тормау сыйфаты. *Яхшы сыйфатлардан янә кроссның продуктлылык дәрәҗәсенең югары торуы һәм кош-корт азыгына талымсызлыгы билгеләнә.* Кызыл таң

2) *күч.* Сайланмау, таләпчәнлек күрсәтмәү, тәнкыйть белән карамау сыйфаты. *Ә тормыш коруда талымсызлыкны берәү дә хупламый.* Т.Миңнуллин. *Гомумән, телгә, сүзгә карата талымсызлык, әледән-әле очрап торган дорфалык һәм ясалмалык пьесаларның түбән җибәрә.* Р.Миңнуллин

3) *күч.* Принципсызлык. *Аның табигатенә һәртөрле кыланчыклык, ясалмалык, талымсызлык бик ят икәнен яхшы беләбез.* Ә.Еники

4) *күч.* Чыдамлык, әрсезлек. *Табигатьнең талымсызлыгына, яшәүчәнлегенә исең китәр.* Х.Камалов

**ТАЛЬ** *и. голл.* Диңгезчелектә һәм төзелештә йөк күтәрту блоклары системасы. *Кырык бер метрлы корыч вышканың бураннан ышыкланмаган югарыгы ягында таль блогының әкрен генә бер өскә, бер аска йөреп торганы күренә: Кәрим Тимбиков вахтасы ныгыту торбалары төшерә.* Г.Ахунов

**ТАЛЬК** *и. гар.* Аксыл яки яшькелт төстәге йомшак минерал. *Шәфкать туташлары, кереп, тальк сибеп чыгып киткән булалар, ләкин моның файдасы шуның хәтле генә.* Ф.Яруллин. --- *Тальк (магний силикаты) – агуларны үзенә көчле суырып, сеңдереп кенә калмый, ә бәлки эчәк юлларын агу сеңүдән саклаучы --- матдә буларак та билгеле.* Агулы үсемлекләр

**ТАЛЬЯН** *и. рус* **1.** Телләр рәте бер генә булган гармун төре. *Авыр уйларны тальян бүлдерде.* М.Мәһдиев. *Иң әүвәл аръякта яшәүче Нәҗметдин абый тальянын сыздырып җибәрә.* К.Тимбикова

**2.** *с. мәгъ.* Телләр рәте бер генә булган. *Иң алгы рәттә, куян мамыклы шәл бөркәнгән хатынына сыенып, тальян гармунын тоткан аучы Гыйлемҗан утыра иде.* М.Мәһдиев. *Алар беренче сыйныфта гына укыйлар иде, Мөнирҗанның иң өлкән абыйсы Гаяз тальян гармун сатып алды.* Н.Әхмәдиев

**ТАЛЬЯ́НКА** *и. рус сөйл. к.* **тальян 1.** *Түгәрәк йөзле яшь кенә егет үзеннән калмыйча авылдан килгән тальянкасына тотынды һәм ниндидер кыска, дәртле көй сузып җибәрде.* А.Әхмәт. *Әхмәтҗан балалары, Шәрифҗаныкылар саратский, казанский, тальянкалардан алып баянга хәтле сыздыралар.* Р.Батулла

**ТАЛЬЯНЧЫ** *и.* 1) Тальян гармунда уйнаучы. *Җырчылар күп, тальянчылар*

*бар, ләкин җанны актарып ташлый торган нәрсәләр җитми.* Р.Газиз. *Махсус чакырткан гармунчылар, тальянчылар милли көйләребезне сузганда, сабантуйлар искә төште.* Хезмәт даны

2) Тальян гармун ясаучы оста. *Әтием – танылган тальянчы, аның гармуннарын күпләр ярата*

**ТАМ** I *и. диал.* 1) Балчыктан койма, түбә ясаганда кулланыла торган балчык

2) Үлгән кешеләрнең табутларын кую өчен, балчык, кирпеч яки таштан салынган кабер өсте корылмасы; гади төрбә. *Каберләр өстендә тамнар да юк. Бары бер кабер өстендә ялгыз таш багана.* И.Салахов

3) Балчык яки таш койма, дивар. *Тавык очса тамга куна, лачын очса – тауга.* Мәкаль

**ТАМ** II *хәб. сүз гар. иск.* **1.** Бөтен, камил, тулы көчендә. *Кодрәтең там язылса, бер фәрманың җитмәс идеме соң тыярга?* М.Гафури

**2.** *кис. мәгъ.* Нәкъ, тач, төп-төгәл. *Бер кеше бер халыкның там яртысын дошман күреп, калган яртысын дус күрәм дип дәгъва кылса, аның бу дәгъвасы ап-ачык бер ялгандыр.* Г.Тукай

**ТАМАДА** *и. груз.* Сый мәҗлесен алып баручы, табынчы. *Әзер табынга унбишләп кеше утырды, тамада итеп мондый мәҗлесләрнең берсеннән дә калмый торган бик борынгы кандидат Кәли иптәшне сайладылар.* Ә.Еники. *Тамада иртәгесен үк тостның нәтиҗәсен күрә!* М.Мәһдиев

**ТАМАДАЛЫК** *и.* Тамада вазифасы. *Сезнең рөхсәт белән, тамадалык вазифасы миңа йөкләнә дип уйлыйм...* И.Юзеев

**ТАМАК** *и.* 1) Үңәч һәм тын юлларының башланып киткән өлеше; бугаз. *Тын алмаслык хәлгә килеп, тамак шеште.* Ә.Моталлапов

2) Муенның өске өлеше, бугаз турысы. *Чыгып җитүенә, ул аны борыны белән аркасыннан, тамак асларыннан сыйпагандай итә, шундук, суык тимәгәе дип, канаты астына – җылыга кертеп җибәрә.* Г.Бәширов

3) Сөйләм органы буларак авыз куышлыгы һәм башка әгъзалар. *Аның белән сөйләшкәндә, Зарифуллинның борын очы тирләде, берөзлексез тотлыкты, элек тә [ң] авазын бик үк яратып бетермәгән тамак, борын куышлыгы кебек фонетик органнары тәмам буталып бетте...* М.Мәһдиев. *Ләкин Сөембикәнең йөзен күрә-күрешкә үк кешеләрнең йөзләре кара коелды, шатлык сүзләре тамактан чыкмас булды.* Р.Батулла

4) Ашказаны. *Ниләр булсын, берни дә юк, мин үзем дә әле өйдә юк идем, кичә генә кайттым, шөкер әле, тамаклар тук.* Г.Камал. *Коданың сырасы бик тә уңган иде инде, тамагым рәхәтләнеп китте.* А.Шамов

5) *геогр.* Елганың башка зуррак сулыкка кушылган яки койган урыны. *Әле генә аларны Җаекта күргәннәр, күп тә узмый Идел тамагына барып чыкканнар да Касыйм ханның бер өлеш малларын куып алып киткәннәр, ди.* Р.Батулла. *Ибраһим паша төмәннәрне яр буенча Дунай тамагына чаклы алып барачак, Яхъя агайга Дубрава аша үтәсе таулы юллар кала.* В.Имамов

6) *күч.* Көндәлек азык-төлек, ашамлык, ризык. – *Син ятып тор, бераз хәл ал, мин тамакка әзерләп алыйм,* – *диде Мостафа, үзен сабыр тотарга тырышып.* Т.Нәбиуллин

7) *күч.* Ризык, азык-төлек запасы. *Ялгызның тамагы җитсә дә, табагы җитмәс.* Мәкаль. *Сугыш һәркемне тамак мәсьәләсенә аек карарга өйрәтте.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Ашау хәстәре; ашау мөмкинлеге. *Солдатларның киемнәре генә түгел, тамаклары хакында да Пётр Алексеевич шәхсән үзе кайгырта.* В.Имамов. *Сездә беренче урында тамак кайгысы... мал-мөлкәт, акча кайгысы...* А.Тимергалин

9) *күч.* Ашыйсы килү, аппетит. *Көткән кешеләрең кайтмый дип тормый тамак дигән нәрсә, үзенекен итә: ашыйсы килә башлады Ханәфинең.* В.Нуруллин. *Энекәш тә тамакка Аллага шөкер.* Ф.Садриев

10) *күч.* Талым, ашны аштан аеру сәләте. *Солтан галиҗәнапларының тамагы бик нәзберек, мәҗлес өстәлләрен мулрак әзерләгез!..* В.Имамов

11) *күч.* Азык кирәк булган гаилә әгъзасы яки терлек башы. *Укымыйча, эшләмичә, кыш буе семья эчендә артык тамак булып яту мәсьәләсе аны туйдыра башлады.* М.Гафури. *Бер тамак артудан бөлерсез шул.* Г.Бәширов

12) *күч.* Тау тишеге, шахта кебек берәр куыш, чокыр формасындагы нәрсәнең керү урыны, авызы. *Бораулау мастеры скважина тамагына бик тиз генә махсус «бөке» алып килә.* Нефть турында хикәяләр

◊ **Тамагына аркылы килгере** Берәр кешегә начарлык теләп, ачуланып әйтелә. *Тамакларына аркылы килгере, уттай урак өстендә бакча артында сырт кыздырып яталар.* Р.Вәлиев. **Тамагыннан өзеп** Үз өлешеннән алып, үзенә дигәнне биреп. *Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын дип, тамагыннан өзеп булса да тырышкан күрәсең инде.* Ә.Еники. **Тамагы тыгылсын** «Гаугачыл кеше биргәнгә канәгать булсын да каршы төшмәсен, дәшмәсен» мәгънәсендә. *Акчаларын да җәлләп тормады Арон Исакович, бер-ике меңен кесә расходларына калдырды да җыенысын илтеп тапшырды хуҗасына, әйдә, тамагы тыгылсын.* К.Кара. **Тамак аеру** *к.* **тамак аралау**. *Аны тамактан аермасалар да, Мәрзиягә алар өлешенә керү уңайсыз.* Ф.Бәйрәмова. **Тамак аралау** Кайбер гаилә әгъзаларын башкалардан ким күреп, кыерсытып, начаррак ашату. *Чит кеше кулында булсак та, безне кагып-сугып җәберләүче, тамак аралаучы булмады.* Ш.Маннур. *Безне какмады, сукмады, тамак араламады, саклады.* Ватаным Татарстан. **Тамак арчу** Сөйләү алдыннан йөткерү, тамак кыру. *Бу тамак арчып алу гөжләве тикмәгә генә булмаган икән.* Р.Төхфәтуллин. **Тамак асрау** Үзеңә ашарлык, җитәрлек ризык табып тору. *Тавык чүпләнеп тамак асрый.* Мәкаль. **Тамак ачу** Ашыйсы килү, ачыгу. *Дөресен генә әйткәндә, табасы белән ашап бетерерлек булып тамак ачкан иде.* Р.Сәгъди. *Унбиш чакрым юлны җәяүләп тә, машина туктатып утырып та Нурия әби ике көннең берендә уза, сумкасында шешә белән сөт, тамак ачканда җәбетеп булса да авызда әвәләрлек икмәк*

*катысы, печәнкә һәм прәннек йөртә башлады.* Ф.Яхин. **Тамак ерту** Акыру, бик кычкырып сөйләү яки җырлау. *--- Алты-җиде яшьлек кызлар, язын тау башына чыгып, теге як кызларын күргәч, тамакларын ерта-ерта җырлыйлар иде ---.* М.Мәһдиев. *Кайсы дурак үзенә дача салмас, Тамак ертып йөреп бу эштә!* Г.Афзал. **Тамак җебетү** *эвф. к.* **тамак чайкау**. **Тамак җылыту** 1) Ришвәт бирү сыйфатында кемне дә булса сыйлау; 2) *к.* **тамак чайкау**. *Мә, энекәш, магазиннан тамак җылытырга алып чык, булмаса...* М.Галиев; 3) Төрле көйләр көйләп тавышны ачу. *Ә үзем белән булган кызык хәлләргә килгәндә, бервакыт, музыка дәресен укытканда, балаларга эндәштем: «Әйдәгез, тамакларыгызны җылытып алыйк әле», – минәйтәм.* Безнең гәҗит. **Тамакка бармау** Ниндидер сәбәпләр аркасында ашый алмый башлау яки бик начар ашау. *Ничек кенә ачыккан кебек тоелса да, тамагына бармады [Хәлимнең].* Г.Гыйльманов. **Тамакка кабу** Ашау, бераз ашау. *Тиз генә тамакка капкалап алам да су коенырга чабарга кирәк дип, өстәл янына килеп утырсам – ике күзем дүрт булды: күрәсең, берәр нәрсә язарга алган җиреннән онытыптыр инде, Кылыч борын теге авторучкасын өстәл өстендә калдырып киткән иде!* В.Нуруллин. **Тамакка сай** Аз ашаучан. **Тамакка таш булу** Кеше өлешенә керү сәбәпле җәзасын күрү турында. **Тамакка таш булып кадалу** *к.* **тамакка таш булу**. **Тамакка таш булып утыру** 1) *к.* **тамакка таш булу** *[Яулап алган җирләр] Бер заман тамагына таш булып утырмасмы аның?* И.Хуҗин; 2) *к.* **тамакка утыру** (*1 мәгъ.*). *Тамакка таш булып утырмаса ашар идем дә...* Г.Әпсәләмов. **Тамакка тимәү** Канәгатьләнерлек, җитәрлек күләмдә булмау. *Комлыкта ятып, су да керә алмау, кем әйтмешли, тамакка тимәде, мыек кына чыланды, кебек була инде ул.* Шәһри Казан. **Тамакка тору** *к.* **тамакка утыру**. *Урлап капкан ризык тамакка тора ул, егеткәем.* В.Имамов. *Әйтте кәҗә, бүре дусның хәлен сорап: – Тамагыңа тормадымы, нихәл, брат?* Г.Афзал. **Тамакка утыру** 1) Тамакка җыелу. *Яңа сауган җылы сөт белән эчеп җибәрсәң тамакка утырмас иде дә соң – аларның сыерлары да, кәҗәләре дә, хәтта тавыклары да юк.* Н.Фәттах; 2) Дөрес булмаган, килешмәгән эшләр турында. *Эшләми ашау тамакка утыра шул ул хәзер.* А.Алиш; 3) Гарык итү, туйдыру. *Тамагымда утыра ул минем*; 4) Сүз әйтелми калу. *Күзләргә яшь тулып, әйтеләсе сүзләр хис дулкыны булып тамакка утырганда, кыңгырау телгә килде.* Авыл офыклары. **Тамак кибү** 1) Су эчәсе килү. *Кичтән туйганчы яңа суйган бавыр ашап чыкканга, тамак та кипкән иде, аны-моны уйлап тормадым, тоттым да бер тында эчеп җибәрдем тегенең чәен.* В.Нуруллин. *Чатнап тамагың кипкән чакта, йотлыгып, бер стакан су эчеп җибәрсәң, аның сихәте шунда ук кан тамырларың буйлап бөтен тәнеңә тарала, шунда ук хәл керә, бөтенләй икенче кеше буласың да куясың.* А.Хәсәнов; 2) Исерткеч эчемлек эчәсе килү. **Тамак киерү** *к.* **тамак ерту**. **Тамак колы** Бары тик ашау турында уйлап йөрүче җан иясе. *Бу «чакырылмаган кунагым» да, әллә шул тамак колы булып, берсеннән-берсе симез тычканнарны эләктерү теләге белән керсә инде.* А.Хәсәнов. **Тамак кыру** 1) Сөйләшми торгач, яки киресенчә, күп сөйләп утырган тавышны ачу өчен йөткергәләп кую; 2) Берәр теләк, кәеф яки хис билгесе буларак тамак төбе белән йөткергән сыман аваз бирү. *Хан уңайсызланып тамак кыра.* А.Гадел. *Һәрхәлдә, минем аяк тавышына, тамак кыруыма, «ау» дип аваз салуыма җавап кайтаручы булмады.* А.Әхмәтгалиева. **Тамак кытыклану** Берәр нәрсәне ашыйсы, эчәсе килү теләге туу. *Тамагы кытыкланып, аракы эчәсе килеп куя [Шәүкәтнең].* Д.Каюмова. **Тамак нечкәрү** Аппетит начарлану яки киресенчә, ризык талымлау, сайлану турында. *Чыннан да аның тамагы нечкәреп калган иде.* Казан утлары. **Тамактан аш үтмәү** Ашыйсы килү теләге булмау. *Бу балаларның берсенә ашатып, икесен ризыксыз калдырсак, кайсыгызның тамагыннан аш үтәр?* М.Мәһдиев; 2) Аш кайнату системасы начарлану, ашый алмау яки бик начар ашау. *Әнисе соңгы вакытларда бик нык бетереште, тамагыннан аш үтми башлады.* Ф.Яруллин. **Тамактан ризык үтмәү** *к.* **тамактан аш үтмәү**. *Бирелдә аш-суны тәмле әзерлиләр, әмма Мәрьямнең тамагыннан ризык үтмәде.* М.Маликова. **Тамактан үтмәү** *к.* **тамактан аш үтмәү**. *Дөресен әйтим, бу ризык минем тамактан үтмәде.* М.Мәһдиев. *Ялгыз башка барыбер тамактан үтмәс иде.* Н.Гыйматдинова. **Тамактан калу** Ашый алмас булу. *Башта Иванга сырхаулыйм дип хәйлә хатлары язды, тора-бара чынлап торып чирли башлады: тамактан калды, сөйләшмәс булды.* Р.Батулла. *Иртән-кичен-көндезен алдына ризык куеп, сабый бала караган сыман карасак та, ул яңа җиргә, яңа хуҗаларга ияләшә алмадымы, әллә берәр чире булдымы, көннән-көн боега барды, тора-бара бөтенләй тамактан калды.* Р.Вәлиев. **Тамактан кире килгәнче** Чамасыз күп итеп. *Тамакларыннан кире килгәнче ашадылар, ләх булганчы эчтеләр, мунчаларындагы кызу ташларга шешәсе белән сыра сиптеләр.* Ә.Мушинский. **Тамактан язу** *к.* **тамактан калу**. *Ул көнне мин бөтенләй тамактан яздым.* Г.Бәширов. **Тамак төбе белән** Ашыкмыйча, кырыс, масаюлы тон белән. *Гитлерчы, тамак төбе белән гырылдап, ике тапкыр номерларны әйтеп чыкты: – Ахтунг!* Г.Әпсәләмов. *Тирә-якта берәү дә юк, әмма карлыкканрак тавыш, тамак төбе белән әйтелгән сүзләр ап-ачык яңгырады лабаса?* Ә.Әминев. **Тамак төбенә тыгылган сөяк булу** Берәүнең ачуын китерү, берәүгә ошамау, комачаулау, эшенә аркылы төшү. *Үзалдына ул, мөгаен: «--- Тамак төбенә тыгылган сөяк булды бит тәмам...» – дип уйлады булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. **Тамак туйдыру** 1) Ашау. *Еланнарның урман-кырларда көн иткәннәре дә күбесенчә тычканнар, бакалар, җирдән сөйрәлүче кош-кортлар белән тамак туйдыралар.* А.Хәсәнов; 2) Көн күрү, яшәү, җан асрау. *Эш хакы турында әлегә сүз кузгатмадык, һәрхәлдә, ул миңа тамак туйдырырга җитәргә тиеш иде.*

А.Тимергалин. **Тамак чайкау** *эвф.* Азрак исерткеч эчемлек куллану. **Тамак чарлау** Җырлау осталыгын камилләштерү максаты белән төрле күнегүләр ясау. *Яздыруга әзерлек йөзеннән, ул шулай итеп урманда тамак чарлап йөри торган булган.* Ватаным Татарстан. **Тамак чылату** *эвф. к.* **тамак чайкау**. *Тамак чылата торгач, күңелләр киңрәк ачыла башлый.* К.Җәмит. **Тамак ялына** *к.* **тамак ялы өчен**. *Бер бай тамак ялына көнлекчеләр яллый.* Мәзәк. **Тамак ялы (хакы, бәясе) өчен (хакына, бәясенә, ялына)** Көндәлек ашауэчү өчен; эш хакы көндәлек ашатуэчертүдән артмау турында. *Аннары үзләре тамак ялы өчен миңа эшкә яллаһалар, ә үз хуҗалыкларын бар дип тә белмиләр.* М.Галәү. *Ниләр генә күрергә һәм кичерергә туры килмәгән сугыш чоры балаларына: ачлык һәм ялангачлык, тамак ялы хакына буыннары да ныгып бетмәгән килеш авыр физик эш башкару алар өлешенә төшкән.* Кызыл таң. **Тамак ялгау** Аз гына ашап алу. *Авылга кайтып, әтине басуга озаткannан соң, тамак ялгарга да өлгермәдем, тыны-көне бетеп, бәрелеп-сугылып, Хәкимҗан килеп керде.* Г.Бәширов. *Тамак ялгагач, Гыйлемдарны йокы баса башлады.* А.Тимергалин. **Тамак яру** *к.* **тамак ерту**. *Берни ишетмәсәләр дә, тамак яра-яра барыбер кычкырдылар.* В.Имамов. *Тургайларны кулдан ычкындырдык, Торна күреп күктә – биектә... Тамак ярдык, юкларны «Бар!» диеп, Булмастайны «Була!» диеп тә...* С.Рәхмәтулла. **Тамак ярыгын майлау** *эвф. к.* **тамак чайкау**

**ТАМАКАЙ** *и. к.* **тамаксау**. **–** *Бик тамакай булмасам да, моны гына булдыра алганымны һәрберегез белә, бүреләр, – дип, башны кашып ала Рагун абый.* Р.Газиз

**ТАМА́К АЛМАСЫ** *и.* Бугаз төере. *Ул Коненконың голт-голт итеп аракы йотуын, йоткан саен, тамак алмасының сикереп куюын күзәтеп, болай уйлап утырды ---.* И.Гази

**ТАМА́К БАКАСЫ** *и.* Кайбер микроорганизмнар, вируслар, гөмбәчекләр китереп чыгара торган, аңкау бадәмчекләре һәм йоткылыкның арткы стенасы ялкынсынуыннан гыйбарәт йогышлы авыру; ангина. *Тамак бакасы (ангина) – йогышлы авыру, ул аңкау миндалиннары һәм йоткылыкның арткы стенасы ялкынсыну белән башланып китә.* Ватаным Татарстан. *Ангина (тамак бакасы) башлануын сизгәч үк, 1 стакан суга 1 чәй кашыгы алма серкәсе, яки 1 стакан суга 1 аш кашыгы тоз салып, көненә берничә тапкыр тамакны чайкарга кирәк.* Мәдәни җомга

**ТАМАК-БОРЫН** *и. җый.* Тамак һәм борын. *Тамак-борынны тикшерә торган врачтыр дип, тыныч кына поликлиникага юнәлде [ул].* Р.Габделхакова

**ТАМА́К ИТҮ** *ф. иск.* Ашау. *Җиһангир бик арыган, кичәдән бирле юньләп тамак итмәгән иде.* Г.Ибраһимов

**ТАМА́К КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тамак итү**. *Тамак кыйлмага вакыт җиткән, барып тамак итәем.* Ф.Халиди

**ТАМАКЛАНУ** *ф.* 1) Ашау, тамак туйдыру. *Юлчылар --- тамаклану нияте илә кечерәк бер елга янына туктадылар.* Ш.Мөхәммәдев

2) Тую, тук булу. *Әй Вәли юмарт, син бу бодайны ашасаң, берүзең берике сәгатькә тамакланырсың, без фәкыйрь ничә мең кырмысканы бер елга ач калдырасың.* Әкият

**Тамакланып алу** Тиз генә капкалап алу, тамаклану. *– Сорыр, әйдә, бер тамакланып алыйк, – ди.* Әкият. *– Егетләрне бераз ял иттереп, үзебез тамакланып алмыйбызмы? – диде.* М.Хәсәнов

**Тамакланып йөрү** *к.* **тамакланып тору**

**Тамакланып тору** Әледән-әле тамаклану; әле, хәзер тамаклану

**ТАМАКЛЫК** *и.* **1.** Ашау-эчү өчен китә торган төрле чыгымнар. *Теге егет илә сторожның тамаклыгына 600 франк яңа расход чыккан.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Тамак туйдырырга җитәрлек. *Тамаклык акча юнәтү*

**ТАМАКСА** *и.* 1) Йөгәнле атның яңакларын аскы яктан уратып ала торган каеш

2) *этн.* Тукымага мәрҗәннәр, тәңкәләр тезеп ясалган, муенга бәйләп куела торган бизәнү әйбере. *Тамбур чигү, хачлап нәкышьләү, тоташ чигү кебек алымнар кулланып бизәлгән бистәрсөлгеләр, ашъяулыклар, милли алъяпкычлар, түгәрәк яулыклар, сүрәкә, тамаксаларның нәфислеге --- хәйран итә.* Мәдәни җомга. *Ә күкрәккә тага торган тамаксалар әбиләрдән калган мирас булып чыкты.* Безнең гәҗит

**ТАМАКСА́У** *с. сөйл.* **1.** Ашарга бик ярата торган, күп ашаучан. *Тамаксау кешенең тамагы шешәр.* Мәкаль. *Ике җиңен сызганып, мырлый-мырлый коштабак-коштабак ит соскан тамаксау кияүдән сөяк өеме генә кала ---.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Ашарга ярата торган, күп ашый торган кеше. *Тамаксауның үлеме тамактан, угрыныкы – таяктан.* Мәкаль

**ТАМАКСАУЛЫК** *и.* Тамаксау булу үзенчәлеге. *Аның тамаксаулыгы, яшенә күрә хәрәкәтчәнлеге дә беркемгә ошамады.* Р.Рахман. *Ул үзенең тамаксаулыгы белән горурлана иде бугай.* Казан утлары

**ТАМАКСЫЗ** *с. сөйл.* Аз ашаучан

◊ **Тамаксыз калу** 1) Тамак авырту; 2) Тавыш бетү. *Учлар кабарганчы кул чаптык, «афәрин!» дип акырышып тамаксыз калдык.* А.Гыйләҗев

**ТАМА́К ТӨБЕ** *и.* Авыз куышлыгының үңәч белән тоташкан урыны. *Иртән тора – хәле юк, тамак төбе авырта, йөрәге еш тибә, томау төшә.* Р.Кәрами. *Менә ул Сөнгатькә нидер пышылдады, тегесе тамак төбеннән аңлаганын белдергән тавыш чыгарды.* Т.Гарипова

**ТАМАКЧА** *и.* Сагалдырык

**ТАМАН** *хәб. сүз* **1.** 1) Билгеле бер үлчәмгә туры килә торган, чак кирәгенчә. *Камыты таман булганда, Хөснулладан алда киләдер идем…* Ш.Камал. *Болай таман үзе, килешеп тә торган шикелле, тик барыбер нәрсәдер җитми кебек.* Р.Миңнуллин

2) Тиешенчә, җитәрлек, кирәгенчә. *Акылым-буем таман, тик бәхетем яман.* Мәкаль. *Уңган кызлар, казаным кайчан кайнап чыгар икән, ашның тозы таман булдымы икән дип, казан өстен ара-тирә ачып-ачып караштыргалаганнар, ялкау кыз бер тапкыр да казан өстен ачмаган, казан кырында йоклап утырган.* Р.Батулла

3) Күп түгел, җитәр-җитмәс, аз. *Акылы таман гына*

4) Берәр кыенлык күрсә, җәза алса – ул аңа артык түгел, шулай тиеш. *Сыных балта сабы --- чуар тавыкка эләккән булса кирәк, --- дөресен әйткәндә, юньләп күкәй дә салганы юк, аңа ни булса да таман.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* Кирәкле температурадагы. *Хуҗа әйтте: «Менә комган Таман су бар, юын, туган».* Г.Афзал

**3.** *рәв. мәгъ.* Тиешле дәрәҗәдә, күләмдә, сыйфатта. *Пилүнинең ике шакмагы бер стаканга таман гына була.* Ф.Әмирхан

**ТАМАНГА́ КИЛҮ** *ф.* Артыкка китмәү, чак кына булу. *Кайвакытта телең белән ялап, чәчең белән җир себерсәң дә бик таманга килә, янәсе...* М.Хәсәнов. *Адәмнең җанын сыйпап, иркәләп торганда да таманга киләдер.* Г.Каюмов

**ТАМАНЛА́У** *ф.* 1) Тиешле үлчәмгә, пропорциягә китерү, таман итү. *Актёр шул дәрәҗәдә образны гәүдәләндерде ки, роль аның үзенә таманлап тегелгән кием дәрәҗәсендә иде дип әйтергә мөмкин.* А.Әхмәдуллин. *Тәбәнәк гәүдәсе юкарган сыман – пиджагы тазарак кешегә таманлап тегелгән кебек.* Р.Кәрами

2) Тиешле температурага җиткерү. *--- бар, әйт: җылы су таманласыннар, яхшы аш-су әзерләсеннәр.* Н.Фәттах

**Таманлап алу** Тиз генә таманлау. *Суны тиз генә таманлап алам*

**Таманлап бетерү** Кирәк кадәр таманлау. *Суны таманлап бетерәм дә, коендырырбыз*

**Таманлап кую** Алдан ук таманлау. *Кунак кыз көянтәсен сыгылдырып, сулы чиләкләрен иплe генә тулгандырып, киез итекләрен шыгырдатып Гайшәттәйләр ягына китүгә, Разак тиз генә тимер таяк, көрәк алып чыгып, кое бурасының биеклеген кызның биленә тиклем таманлап та куйды.* Авыл офыклары

**Таманлап тору** Даими яки әледәнәле таманлау; әле, хәзер таманлау. *Сеңеле бала коендырырга су таманлап торды*

**Таманлый төшү** Бераз таманрак итү. *Күлмәкнең җиңнәрен таманлый төш әле*

**ТАМАНЛЫК** *и.* Таман булу сыйфаты. *Чираты артык зур булганлыктан, кибеттә аның таманлыгын, килешкилбәтен чамалап торырга туры килмәде.* Ф.Яруллин

**ТАМА́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Тиешле чамада, санда, күләмдә, пропорциядә. *Иген осталары, бер метрга алты йөз пот чамасы туры килсә, таманча була, дип язалар.* Г.Бәширов. *Матур булып, таманча гына кызарып пешкән тәбикмәкләрне эретелгән ак май белән майлап, табынга бирергә.* Өмет

2) Бик үк мул түгел, уртача. *Тик сыебыз гына таманчарак.* С.Рафиков

**2.** *с. мәгъ.* Тиешле чамадагы, күләмдәге, зурлыктагы, сандагы, пропорциядәге, уртача. *Озын-озак эссе көндә җылынган су инде суынырга өлгергән, таманча салкынлыктан тәндәге бөтен күзәнәкләргә рәхәт сулкылдау тарала иде.* Р.Мирхәйдәров

**ТАМА́НЧАЛЫК** *и.* 1) *к.* **таманлык**

2) *сөйл.* Акылсызлык, акыл зәгыйфьлеге

**ТАМАНЫСЫ** *ы.* Нәрсәдәндер тәмам туюны, шуны туктатып калырга тырышуны белдерә; җитте. *Я, җитте инде, җитте, тавышыңның таш ярырдай икәнлеген аңладым лабаса: таманысы, булгач та булырсың икән, уф ---.* С.Поварисов

**ТАМАША** *и. гар.* **1.** 1) Нинди дә булса кызык күренеш, вакыйга. *Бер авыл малае гомердә күрмәгән тамашаларны күреп, арттагылардан бөтенләй кул селтәве бик мөмкин.* М.Фәйзи. *Көрәштән кала иң зур тамаша – ат чабышы.* Г.Галиева

2) Бик матур, искиткеч күренеш. *Су буенда гаҗәп матур җирләр, шунда ук әрәмәлек, балыклы күлләр... Җәй көне бер тамаша инде менә.* Ш.Камал. *Үткән вакытта шул мәйдан аша Була искиткеч гүзәл тамаша.* З.Мансур

3) Шау-шулы, ыгы-зыгылы күңелсез күренеш яки хәл. *Хәлимнең маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Бу ни тамаша! Ой, ой! Әнә зениткалар ата да башладылар.* Г.Гобәй

4) Халыкка махсус әзерләп күрсәтелә торган күренеш, уен яки сәхнә әсәре. *Мондый беркайчан да күрелмәгән тамашаны карау өчен, бөтен шәһәр халкы җыйнала, халык, бик зур төркем булып, маймыл артыннан патша сараена хәтле килә.* Әкият. *Бу тамаша залда утыручыларга бик кызык тоелды.* Ф.Яруллин

5) *күч.* Нинди дә булса берәр үзлеге белән хәйран калдырырлык нәрсә. *Ул кызларның ничек интегүен күрсәң... Тамаша...* А.Тимергалин. *Иртәнге чыкка чыланып, билдән чат су булып, шушы аланга килеп керсәләр – тамаша! Әлеге имән тирәли бер өер этмаэмай балалары мәш килеп әүмәкләшәләр.* А.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Искиткеч шәп. *Бал аша да май аша – Көн итәрсең тамаша.* Ш.Маннур

2) Бик күп; кадәрле; хәтле. *Кайда шул тамаша эчкән соң ул [Тимбиков]?* Г.Ахунов

3) Бик, гаять, чиктән тыш. *Югыйсә бу тамаша авыр чемоданны апкайтып җиткерә алмассың!..* В.Нуруллин

◊ **Тамашага калу** Соклану, таң калу, гаҗәпләнү. *Халык Бәһрамны мактый, аның һөнәре турында тамашага калып сөйли.* Ш.Әхмәдиев

**ТАМАША́ ИТҮ** *ф.* Кызыгын табып, игътибар белән карап тору. *Автобус эчендәге халык һаман салмыш ир белән кондуктор кызны тамаша итеп, аларның һәр сүзенә рәхәтләнеп көлә иде.* И.Нәбиуллина

**ТАМАША́ КЫЛУ** *ф. к.* **тамаша итү**. *Хәйретдин кияү егетедәй бизәлгән кырык корабыннан ярга бүләк артыннан бүләк ташыта башлагач, моны тамаша кылырга дип җыелган пайтәхет халкының һәммәсе аһ итте.* В.Имамов. *Шушы мәшәкатьле вә борчулы көннәрдә Йосыфны энесе Исмәгыйль бәк тамаша кылырга чакырды.* М.Әмирханов

**ТАМАШАЛЫК** *и.* 1) Табигый феномен, борынгы хәрабәләр һ.б.ш. тамаша кылырга, карарга лаеклы, кызыклы урын

2) Җәлеп итүчәнлек, тамаша кылырлык дәрәҗәдә матурлык, кызыклылык. *Хореография: башкару техникасы, индивидуальлек, стиль, татар биюе стилизациясе элементлары, тамашалык,*

*сценография, сәхнә культурасы, артистлык, сәхнә образын тудыру, үзенчәлелек, хислелек.* Сәхнә

**ТАМАШАЛЫКЛЫ** *с.* Тамаша кылырлык. *Тамашалыклы урыннар*

**ТАМАШАХАНӘ** *и.* Тамаша куелу бинасы. --- *мөхәррир әфәнде үзе шундый бер уенда хазир булса, тамашаханәдән, әлбәттә, мәэюс булып кайтачактыр.* Г.Камал

**ТАМАШАЧЫ** *и.* 1) Тамаша караучы кеше. *Җиде-сигез мең тамашачы алдында чыгыш ясауның уен эш түгел икәнен тоеп булса кирәк, барысы да үз номерларын әйбәт башкардылар.* В.Нуруллин. *Хәтта артист та сәхнәгә тамашачыны яуларга дип чыга, ул да тамашачы минем властьта дип уйлый.* З.Хәким

2) Вакыйгаларга катнашмыйча читтән генә карап, күзәтеп йөрүче кеше. *Шуңар күрә мин мондый вакыйгаларга тамашачы булып кына кала алмыйм.* Ә.Еники. *Үз чорында барган вакыйгаларның тамашачысы булып калу чын художник эше түгел.* М.Хәсәнов

**ТА́МБУР** I *и. фр.* **1.** 1) Махсус энә – бик очлы башлы ыргак энә белән чәнчем-чәнчем чылбырсыман чигү төре. *Алъяпкычта тамбур белән чиккән гөлҗимешләр...* А.Гыйләҗев. --- *минем сандыкта әллә күпме тамбур җебе ята, шуны бирермен.* Г.Якупова

2) Шул рәвешчә ясалган җөй. *Тамбурлар белән чигелгән Бизәкле чүәкләрем.* С.Хәким

**2.** *с. мәгъ.* Тамбур белән чигелгән. *Матур, затлы булудан тыш, тагын әллә нинди әйтелмәгән серләре бардыр ул чигүле түрләмәләр, тамбур җөй белән башкарылган чигүле келәмнәрнең.* Шәһри Казан

**ТА́МБУР** II *и. фр.* 1) Вагонның баш-башында тышкы ишегә белән эчке ишегә арасындагы мәйданчык. *Ә көннәрнең берендә ул төнге пассажир поездының тамбурына кереп урнаша алган.* М.Мәһдиев. *Берничә станцияне тамбурда басып үткәннән соң, вагон тулы халык арасына кереп кысылдык.* Ф.Хуҗин

2) Ишек төбе корылмасы яки гөмбәз түбәле өйалды. *Алгы бүлмә белән өйгә керә торган ишек арасына җылы тамбур ясарга кирәк.* Йорт эшләре. *Эвакуация ишекләре һәм юлларын (шул исәптән, коридор, тамбур, галерея, баскыч мәйданы, баскыч маршлары, ишекләр, эвакуация люклары) төрле материаллар, җиһазлар, производство калдыклары, чүп-чар һәм башка әйберләр белән тутырырга ярамый.* Идел таңнары

**ТАМБУ́Р** III *и. к.* **танбур**. *Бәләкәй Бөкре кушаматлы бер кеше, бусагага утырып, үзенең тамбурында моңлы көйләр уйнап җырлый башлады.* Мең дә бер кичә

**ТАМБУРЛЫ** I *с.* Тамбурлап чигелгән. *Аның өстендәге җиңелчә яхшы кара кеш туны, кызыл тамбурлы биек читекләре, башындагы кызыл таҗ кәләпүше, кара айгыры – һәммәсе үзенә бердәй килешеп тора иделәр.* Ф.Яхин

**ТА́МБУРЛЫ** II *с.* Тамбуры булган. *Ингель уртадагы тамбурлы ике ишекне дә ябып куя.* Х.Камалов

**ТАМБУРЧЫ** *и. к.* **танбурчы**. *Тамбурчылар белән кубызчылар залның сул ягындагы ишек артына кереп утырганнар, уң канаттагы ярымтүгәрәк сәхнә мәйданында биллләренә бияләй чаклы гына ефәк япма аскан биюче кызлар еландай бөтерелә.* В.Имамов

**ТА́МБУР ЭНӘСЕ** *и.* Күз урынына ыргакчыгы булган махсус чигү энәсе. *Ак тастымалның бер читендә тамбур энәсе белән шундый сүзләр язылган иде: «Сапуан абыйга истәлек».* З.Мәхмүди

**ТАМГА** *и.* 1) Сызып, киртләп, көйдереп һ.б.ш. ысуллар белән төшерелгән шартлы билге. *Тамганы да бер сугуда салырга кирәк: тамга ачык, туры булып, бүрәнә башының өске кырыена, билгеле бер урынга төшсен.* Г.Әпсәләмов. *Хет рубльгә бер тамга сырла ---.* И.Гыйләҗев

2) Имза функциясен үти торган берәр зат, ыру, кабиләнең шартлы билгесе. *Кайсы да булса берсе, үрелеп, эшләпәдән хуҗалыкларның тамгалары салынган юкагач шобага ала.* Г.Бәширов. *Ул аптырады, йөдәде: ярый, бу таныш тамганың кай ырунықы икәнен хәтерләмәү табигый, ә менә бер үк затлы капка тамганың өйрәнчек кул белән әвәләп ясалган җәбәхәер савытларда да, аксөяк нәсел батырының яу җәясендә дә булуы гайре табигый хәл сыман тоелды аңа.* Р.Батулла

3) Имза. *Ошбу протоколга мәҗлестәге членнар бар да, кул куеп, тамгаларын салдылар.* Ш.Мөхәммәдев. *Ишетүемә караганда, губернаторга керү өчен, Печән базарыннан Гайнетдин бай безгә каршы тамга җыеп йөри, ди.* И.Юзеев

4) Аерым кешеләр, оешмалар тарафыннан җәмгыятьтә аларны, аларның эшләнмәләрен танып алу өчен кулланыла торган махсус сурәт, график билге, символ; логотип. *Ул ясаган тотка, күгән, келә, кадак суыргыч һәм чүкечләрнең һәрберсендә останың үз тамгасы бар: «Г.Барый», ягъни Габдерахманов Барый.* Р.Газиз. *Минемчә, ул үзенең фирма тамгасын беренче тапкыр кулланырга җөрьәт иткәндер әле.* А.Тимергалин

5) Мөһер, пичәт эзе

6) Мал-туарның, кош-кортның яшен, хуҗасын белгертү һ.б. өчен терлекнең берәр җиренә төшерелгән, буялган яки тагылган билге. *Җуялмасын, тамга булсын өчен, кайсыбер әтәчләрнең дә тәпиләренә шундый чүпрәк тегеп куялар бит.* Ф.Әмирхан

7) Шартлы мәгънә белдергән билге. *Ярый әле, чатта светофор бар. Ярый әле, урам чатларында – Кисәтү һәм тыю тамгалары.* Г.Морат

8) Билгеле бер мәгълүматны бирү өчен кулланыла торган график билге белдерү чарасы. *Шуның хәрефләрен барлап чыккач, стенографик тамгаларын да беләм булып чыкты!* Ф.Баттал. *Тамгалары бер төрле булган ике санны кушу өчен, аларның абсолют зурлыкларын кушарга кирәк.* Алгебра

9) Компьютер программаларында күрсәтелгән опцияләрнең, пунктларның берсе. *Гадәттәгечә, инетта (яшьләр үзара интернет сүзен шулай кыскартып әйтә) утырганда, чираттагы берәү «дуслык сорады», «дуслашу» тамгасына бастым.* Безнең гәҗит

10) *тар.* Салым төре. *Тамгачийан (тамгачылар) – «тамга» дигән бер төркем салымнарны җыючы түрәләр*

*булса кирәк. Тамга – гадәттә шәһәрләрдә сәүдә һәм һөнәрчелек шөгыльләреннән җыелган бер төркем салымнар.* Гасырлар авазы

11) *күч.* Хайваннарда икенче төс белән аерылып торган җир, тимгел, тап. *Мәченең койрык очында ак тамгасы бар.* Әкият

12) *күч.* Эз, билге. *Һич югында, җир өстендә бер-бер тамгам калыр...* Сөләйман. *Бөтен ил буенча «ликвидатор» исеме һәм мәңге бетмәс куркыныч атом тамгасы алган кешеләр сибелеп яши.* Безнең гәҗит

13) *күч.* Халык теленә кергән атама, яманат һ.б.ш. *Син дәҗҗал кылган явызлыклар, әшәкелекләр һәрчак безнең күңелләрне бимазалап торыр, нәселнәсәбеңә мәңгегә хурлык тамгасы булып тагылыр.* Ф.Садриев. *Димәк, мин гомерем буе шушы тамганы күтәреп йөрергә тиеш.* А.Әхмәтгалиева

14) *күч.* Әйбернең билгеле бер үзенчәлеген күрсәткән язу. *Инде чыгып барганда, Асия аңа «ашыгыч» дип тамга сугылган телеграмма сузды.* В.Имамов. *Инде шул чорның рухы һәм эш алымнарын чамалау өчен, «соң дәрәҗә яшерен» тамгасы куелган кайбер документларга сүз бирик.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Тамга салу** Билгеле фикергә килү һәм хәл итү. *Егерменче елда Гани байдан Тула тегермәнен алдылар. Алдылар да картлар: «Кәрим картка бирәбез!» – дип, Тамга салдылар.* Ш.Маннур. **Тамга салыну** Нинди дә булса югары көчләр тарафыннан алдан билгеләнгән булу. *Миңа ул күк тарафыннан тамга салынган шәхес кебек тоела иде. Шәех Зәбиров – журналистикага, язу-сызу дөньясына бөтен тормышын багышлаган кеше.* Ватаным Татарстан

**ТАМГА́ ЙОРТЫ** *и. сир.* Читтән кертелә торган товарлардан тамга малы, хак алу оешмасы; таможня

**ТАМГАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тамгалау**. *Мәсәлән, шул ук торакны (элеккеге «Франция» номерларын): аның иләмсез биек түшәмле, ун-унике кеше сыярлык зур бүлмәсен, бүлмә уртасында кара белән буялып, пычак белән тамгаланган озын, шәрә өстәлен, бакыр чәйнеген, калай кружкаларын, ниһаять, тар, шыгырдавык тимер караватын...* Ә.Еники. *Дошманның зенитка батареялары урнашкан урыннар аерым билге белән тамгалана, аэродромнары бoҗрага алына, аларны ничек тә әйләнеп узарга тырышалар.* Ф.Хуҗин

2) Берәр нәрсәгә буялып яки бәрелеп һ.б.ш. юл белән билге, эз ясалу. *Забойда озак эшләгән шахтёрлар җир астыннан шулай тамгаланып чыгалар.* Г.Гали

3) Махсус тамга, билге аркылы белдерелү. *Башкаларның билгеләре икеле дә өчле булса, бер минеке генә дүртле бәясе белән тамгаланган иде.* Ә.Рәшит. *Тигезләмәнең хәрефләр белән тамгаланган берничә билгесезне эченә алуы мөмкин.* Алгебра

**Тамгаланып бару** Рәттән, даими тамгалану. *Бу күрсәткечләрнең һәркайсы тамгаланып барып, соңыннан нәтиҗә ясалачак. Укучының белеме яхшырганмы, юкмы – шуннан барысы да беленәчәк.* Ватаным Татарстан

**Тамгаланып бетү** Булган бер җире тамгалану

**Тамгаланып тору** Даими яки әледәнәле тамгалану; әле, хәзер тамгалану

**ТАМГАЛА́У** *ф.* 1) Тамга салу, тамга төшерү; тамгалы итү. *Барысын да дөрес тамгалаган бит, каһәр!* Ф.Баттал

2) Имзалау, имза яки мөһер белән раслау. *Үрдә утыручыларның кайсыберләре: «Патшага прошение бирергә барганын становой белсә, тагын бер унбиш таяк өстәтер иде моңар», – дип уйласалар да, ул турыда сүз кузгатучы булмады. «Тамгалау» эше карыйдан соң вакытлыча туктатылды.* М.Галәү. *Ибраһим, Искәндәрне сарай бакчасына көйләнгән дарга чыгарып асарга, дигән фәрманны тамгалады.* В.Имамов

3) *мат.* Билге кую. *Санау системасы – саннарны тамгалау ысулы һәм саннар өстендә башкарыла торган гамәлләр кагыйдәләре ул.* Г.Мөхәрләмова

4) *күч.* Авыр тәэсир итү, күңелдә яра калдыру. *Тамгалады безне җил-давыллар, әвәләде бераз, билгеле.* Х.Туфан

5) Ямьсез эз, тап калдыру

6) *күч.* Тискәре бәя бирү. *Дөрес, ул дәверемне, «тоташ бәхетсезлек чоры» дип тамгалап, сызып ыргытырга җыенмыйм.* И.Гыйләҗев. *Ахмак (начар) кешеләрне исән чагында таяк белән шуның өчен кыйнарга кирәк, чөнки, үлгәчтен, янә тагы бер кат хурлап, мыскыл белән тамгалап, җәзалап булмый.* М.Мәһдиев

**Тамгалап алу** Тиз генә тамгалау

**Тамгалап бару** Эзлекле рәвештә тамгалау. *Аның каләменнән төшкән башлам яисә соңгы сүздә фикерләү киңлеге, әдәбиятка хуҗаларча карап, аның көчләрен барлап, юнәлеш биреп, киләчәк үсеш юлларын тамгалап баруы искитмәле.* Т.Галиуллин. *Шулай ук командировка, сәяхәт вакытында куна кергән йорт хуҗаларының йөзкыяфәтен тасвирлап, аларга булган беренче тәэсирләрен дә көндәлегенә тамгалап бара.* Л.Гарипова

**Тамгалап бетерү** Булган берсен тамгалау. *Булгач булсын инде, бер тотынгач, барысын да ачыклап, тамгалап бетерик.* Ф.Баттал

**Тамгалап килү** Күптәннән үк эзлекле рәвештә тамгалау. *Без ничә дистә ел буе яхшы белән яманны берьяклы идеологик мөһер белән ансат кына тамгалап килдек.* Т.Әйди

**Тамгалап кую** Алдан тамгалау; шушы вакытта, әйтелгән вакытта тамгалау. *Сираҗетдин Кәримовны да тамгалап куй әле.* Ф.Бурнаш. *Акча аның кесәсенә керү белән, кинәт оперативниклар пәйда була һәм Роспотребнадзор вәкиленнән үзләре үк тамгалап куйган меңлекләрне тартып чыгара.* Безнең гәҗит

**Тамгалап тору** Даими яки әледәнәле тамгалау; әле, хәзер тамгалау

**Тамгалап чыгу** Рәттән барысын да тамгалау. *Әтәчләреңне – бер төс, тавыкларыңны башка төс белән тамгалап чыгу өчен...* Ф.Баттал. *Бу телләрдә «арыш анасы», татарчадагы шикелле үк, арышта була торган көрән гөмбәчекне дә белдерә, чөнки шундый гөмбәчекләр белән арыш анасы үзенә дип калдырган башакларны тамгалап чыга дип уйлаганнар.* Р.Әхмәтьянов

**Тамгалый бару** Бер-бер артлы тамгалау

**Тамгалый башлау** Тамгаларга тотыну. *Эш шунда ки, күмәк хуҗалыклардагы*

*күпсанлы малкайларны, буташтырмас өчен, тугач ук тамгалый башлыйлар.* Безнең гәҗит

**ТАМГАЛЫ** *с.* 1) Тамга төшерелгән, тамгасы булган, тамга белән билгеләнгән. *Ул әтидән бармак озынлыгы, урталай ярылган тамгалы сөян кисәген ала да шуның киндер башына тагылган икенче яртысын эзләргә тотына.* Г.Бәширов. *Соңгы олаучының кайтуын ул койма өстендә көтеп торды, хан теркәүчеләре биргән тамгалы язуны күздән кичерде.* Н. Фәттах

2) Нурланыш туплаган, радиоактив. *Нурланыш туплаган атомнарны фәндә тамгалы атомнар дип атыйлар.* Татарстан яшьләре

**ТАМГАЛЫК** *и.* Читтән кертелгән мал өчен түләнә торган бәя, пошлина. *Моннан соң инде Болгар сатучылары берниндi тоткарлыксыз, берниндi тамгалык түләмичә, Урыс җиренең иң аргы төбәкләренә үтеп керә алачаклар.* Н.Фәттах

**ТАМГА́ МАЛЫ** *и. иск.* 1) Чит дәүләттән рөхсәт белән кергәнлеген белдереп, тамга сугылган товар

2) Читтән товар кертү яки чыгару өчен, хөкүмәткә түләнә торган акча яки товар. *Гаскәрләрнең башлыклары --- тамга басып, икенче мәртәбә, Болгарга җиткәнче, тамга малы алмаска, дип язу биреп, китәргә рөхсәт иттеләр.* Г.Гобәйдуллин. --- *Төркестан, Бохара, Хива кәрваннары – барысы да алар аша үтә, чин, гарәп маллары да шунда керә, бөтенесе өчен тамга малын татарлар ала!* Ф.Бәйрәмова

**ТАМГА́ ӨЕ** *и. сир. к.* **тамга йорты**. *Яр буенда, тамга өендә аны базар башы Бигеш каршылады.* Н.Фәттах

**ТАМГА́ САЛЫМЫ** *и.* Пошлина, таможня тарафыннан җыела торган салым. *Аннары син минем сәүдәгәрләремнән француз мәмләкәтендә тамга салымы талама, мин синекеләрне ышыгыма алам.* В.Имамов

**ТАМГАХАНӘ** *и.* Читтән кергән әйбер-товарлар тикшерелеп, алар исәбеннән тамга малы алына торган урын, таможня. *1892 елның 13 февралендә Муса Акъегетзадә өстәмә бер вазифа ала: Галата тамгаханә (таможня) идарәсенә тикшерүче итеп билгеләнә.* Гасырлар авазы. *Татар теленең үз җирлегендә яңа терминнар да ясалды: кертем, кертемче, тамгаханә, арзулык һ.б.* Фән һәм тел

**ТАМГАЧЫ** *и.* 1) Тамга салучы. *Хан идарәсендә сәркатипләр (секретарьлар), хисапчылар, күчереп язучылар, тамгачылар (мөһер сугучылар) эшләгән.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Тамгаханә хезмәткәре, таможнячы. *Күпер төбендәге ул таш йортта гадәттә төнге кизүләр, күпер сакчылары, тамгачылар була.* Н.Фәттах. *Ошбу таләпләрне барча әмирләр, хакимнәр, сәедләр, казыйлар, вәкаләтле адәмнәр, түрәләр, төбәк башлыклары, сакчылар, тамгачылар колакларына киртләсеннәр.* М.Әмирханов

3) *тар.* Салым җыючы. *Тамгачийан (тамгачылар) – «тамга» дигән бер төркем салымнарны җыючы түрәләр булса кирәк.* Гасырлар авазы

**ТАМГАЧЫ-ТАРТНАКЧЫ** *җый. и. тар.* Тамга салучы һәм салым җыючылар, тамга салып салым алучылар. *Үзәндәге кара чабаннар, амбарчылар, чуралар, тамгачы-тартнакчылар, ямьчеләр Алып Бәрән батырны Гыйфриткә каршы сугышка озата барды.* Р.Батулла. *Туктамыш һәм Сәгадәт-Гәрәй хан ярлыкларында тамгачы-тартнакчылар телгә алына.* Гасырлар авазы

**ТАМГЫ** *и. гар. иск.* Нәрсәне дә булса бик нык теләү, азгын нәфес, теми. *[Абелкарип:] Куегыз, ганкалар, тамгыгызны сузмагыз.* Т.Гыйззәт

**ТАМГЫ́ ИТҮ** *ф. иск.* Нәфесләнү; ачкүзләнү

**ТАМГЫ́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тамгы итү**. *Мәгарәдән чыккач, кешеләр тамгы кыйлып алмасыннар өчен, гаять кирәк булганнарын суган суы белән язып алдылар.* К.Насыйри

**ТАМГЫЛЫ** *с. иск.* Нәфесле; ачкүзле. *Муса... бозык күңелле, эттән зиядә тамгылы, ачкүзле вә һич сакланмай гайбәт сөйләүче иде.* Р.Фәхретдинов

**ТАМГЫЧЫ** *и. иск.* Хәер-садака өмет итеп йөрүче кеше. *Зәки --- чын хәерче, сәдакачы вә тамгычы булды.* М.Максуд

**ТАМДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **таму**. *Үзәкләрен өзеп аналарның, Аналарның яшен тамдырып, Бала туа, җиргә бала туа, Бар дөньяны хәйран калдырып.* С.Рәхмәтулла

2) *сөйл. к.* **тамызу**. *Бераз тамдыру*

**ТАМИЛ** *и.* Көньяк Азиядә яшәүче халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Шунда чалмалы тамил (Шри-Ланкадагы төп милләт) киндер каплавычлы тубалын ачты.* М.Мәһдиев. *Шри-Ланканың берничә тамил һәм мөселман сәяси партиясе, илдәге милләтара проблемаларны хәл итү максаты белән, берлек оештырырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килгән.* Ватаным Татарстан

**ТАМЛА́У** *ф. диал.* Таму. *Тамчы-тамчы тамласа, Каты таш та тишелә.* Мәкаль

**ТАММ** *хәб. сүз гар. иск. к.* **там** II. *Соңгы елларда фәндә, күчмә кабиләләрдә – һуннарда һәм борынгы төркиләрдә – үзенчәлекле, ләкин тамм кыйммәтле дәүләт булган, дигән фикер урнаша.* Фән һәм тел. *Русия мөселманнары хокукларның һәрберенә, вазифаларның һәрберенә әһел булу сыйфаты илә, дәүләттә тамм хокуклы әгъза булып, сәяси, иҗтимагый идарәләрнең һәрберенә һәр җәһәтилә иштирак итәр (катнашыр).* Гасырлар авазы

**ТАМО́ЖНЯ** *и. рус* Чит илдән кертелә яки чыгарыла торган товарларны тикшерү һәм махсус пошлина алу учреждениесе; тамгаханә. *Итальян пароходына яшерен төстә утырып Кырымнан Бакуга китүләр, инглиз яугирләре тентүе, таможня, төрле юл маҗаралары хакында ул сәгатьләр буе сөйли торган иде.* Р.Әмирхан. *Яңа көн – яңа хәбәр. Озакламый Татарстан таможнясында кинологлар хезмәте эшли башлаячак.* Ватаным Татарстан

**ТАМО́ЖНЯЧЫ** *и.* Таможня хезмәткәре. *Г.Апанаев – татарның беренче таможнячыларыннан, 1920 елларда ул Владивосток таможня идарәсе җитәкчесенең ярдәмчесе булып эшли, бу турыда да документлар сакланган.* Гасырлар авазы. *Таможнячылар законсыз йөкне ветеринария инспекциясенә тапшырган.* Ватаным Татарстан

**ТАМПОН** *и. фр.* 1) *мед.* Кан туктату, эрен чыгару яки корыту өчен, ярага, куышлыкка куела торган зарарсызлан-

дырылган мамык яки марля кисәге. *Ә менә ефәк тукымадагы тапны аракылы тампон белән эшкәртәләр.* Ватаным Татарстан. *Борынга суган яки алоэ согында чылатылган тампон куеп тору да иркенләп суларга һәм авызны ябып йокларга мөмкинлек бирә.* Мәдәни җомга

2) *тех.* Сыеклык яки газ ага торган берәр куыш нәрсәнең авызын томалау чарасы. *Нефтьүткәргечкә тампон кую. Туп көпшәсен тампон белән томалау*

**ТАМПОНАЖ** *и. фр. махс.* Тау эшендә, гидротехник төзелештә, бораулау скважиналарында токымнар арасындагы бушлыкларны цемент, балчык, битум белән тутыру алымы. *Элек автоколонна транспорты буровойлар өчен измә әзерләп, аны ташу белән шөгыльләнсә, хәзер исә өстәмә рәвештә тампонаж эшен дә үзләштердек.* Маяк. *Октябрьский техникумын тәмамлаганнан соң, 20 яшьлек егет хезмәт эшчәнлеген «Әлмәтбурнефть» трестының тампонаж конторасында машинист булып башлый.* Байрак

**ТАМПОНАЖЧЫ** *и.* Тампонажны башкаручы эшче. *Азнакай тампонажчылары өченче урынны яулады.* Маяк. *Скважинаны җибәрүдә көйле рәвештә берьюлы бернич әкатнаш тармаклар – транспортчылар, геофизиклар, тампонажчылар, энергетиклар һәм башкалар катнаша.* Әлмәт таңнары

**ТАМПОНЛА́У** *ф.* Тампон кую

**ТАМТАЛ** *и. сөйл.* Утлы тәмуг, җәһәннәм. *Китереп торып берне соссам, тамталлар арасына тәгәрәп китәрсең.* Г.Гобәй

**ТАМТАМ** *и. һинд* 1) Көньяк-көнчыгыш Азиядә таралган тимер бәрмә уен коралы, гонгның бер төре. *Ул менә без – ударниклар. Тамтамнар да чаңчаңнар. Шулай булгач, хөрмәт – безгә: Оркестрның көче бездә.* Җ.Фәйзи

2) Африкада таралган, күн урынына агач куелган барабан төре

**ТАМТАТАРАЙ** *и. гр.* Җәһәннәм, тәмуг; тартар. *[Поп:] Әгәр яңадан патша куймасак, бөтен Россия зир-зибәр тамтарарайга дөмегәчәк.* Г.Бәширов

**ТАМУ** *ф.* 1) Тамчы булып яки тамчы-тамчы булып төшү. *Фәкать краннардан берәм-берәм тамган тамчыларның тавышлары гына бу тынлыкка үзенә бертөрле эчпошыргыч хәят бирә иде.* Ф.Әмирхан. *Шундый тын, хәтта миләш бөреләренә эленгән яңгыр тамчыларының күз яшедәй җиргә тамуына хәтле ишетелә.* Г.Бәширов

2) Тамчылап яки акрын гына агып төшү. *Бал тамган телдән агу да тамар.* Мәкаль

3) *күч.* Өзелеп төшү; атылу. *Тып итеп, башына бер алма «тамды».* Н.Гыйматдинова. *Төне буе, Төне буе йолдыз тамды. Соңгы күзәнәккә хәтле Яндым менә.* Л.Зөлкарнәй

4) *күч. шигъ.* Чәчелү, сибелү, бөркелү. *Таң нурлары тамды бу кырларга, Мин алардан серләр эзләдем.* Р.Әхмәтҗанов. *Каен тәлгәшеннән моңнар тамып Сагыш басса, яшьләр түкмә әле!* М.Шиһапов

5) *күч.* Материаль байлык, файда керү, кемнән дә булса өлеш чыгу, ярдәм тию. *Уң яктан сиңа тама, Сул яктан сиңа керә. Бераз гына керми торса, Йөрәк шартлар чиккә җитә.* А.Гадел. *Гомерем буе язып, миңа бит, ниһаять, нәрсә дә булса тамарга тиештер.* З.Хәким

**Тама башлау** Тамарга тотыну. *Мөселман яугиренең күзләренә маңгаеннан аккан тир тамчылары тама башлагач, җәллад драгун мәкерле рәвештә әүвәл аның кулсыз иңбашына кылыч кадады, аннары, яман кизәнеп, муенына чапты.* В.Имамов. *Шул хакта уйлап кына өлгергән, кызның күзләреннән яшь бөртекләре тама да башлаган.* Г.Гыйльманов

**Тама төшү** Күбрәк, ешрак таму; бераз таму. *Димәк, авылларыбызның көндәлек тормышын кайгыртучы, аларның мең дә бер төрле мәшәкатьләрен хәл итүче авыл җирлекләре бюджетына керем тама төшәр иде.* Әлки хәбәрләре

**Тамып алу** Бераз вакыт таму

**Тамып бару** Даими таму. *Берәрсенең дәүләт казнасына салымнары тамып бармаса, субсидия тәтемәячәк.* Безнең гәҗит

**Тамып бетү** Тулысынча таму; тамудан туктау. *Капельницадагы дару тамып бетсен дә, мин сиңа урамны күрсәтермен.* З.Кадыйрова. *Күңел тула, тик агасы күз яшьләрем узган төндә бары да берьюлы тамып беткән, ахры.* Безнең гәҗит

**Тамып китү** Кинәт тамарга тотыну. *Күзләреннән яшьләр тамып китә бу хатынның*

**Тамып кую** Бер генә мәртәбә яки бик аз гына таму. *Анда инде башкасы да тамып куячак.* Н.Фәттах. *Яңа гына явып үткән яңгырдан үләннәр юеш иде, җылы пар күтәрелеп, күңелләрне иркәли, агач яфракларыннан төшеп өлгермәгән яңгыр тамчылары сирәк кенә тамып куя.* Д.Каюмова

**Тамып тору** Берөзлексез яки әледән-әле таму; әле, хәзерге вакытта таму. *Шунда патша каршында үсеп утырган агачны күргән, ә агачтан майга охшашлы су тамып тора икән.* Әкият. *Күлмәкләр тәнгә сылашкан, ыштан балакларыннан тамчылар тамып тора.* Г.Бәширов

**Тамып утыру** *сөйл. к.* **тамып тору**. *Адәмчә генә сөйләшеп, моңаешып, хәтта күз яшең тамып утырган чакта да шыркылдап, бот чабып көлергә мәҗбүр итә бит бу хәерсез үзенең тузга язмаган сүзләре белән.* Ф.Баттал. *Су тамчысы да бит, акрын гына тамып утырса да, үзенекен эшли: ахыр чиктә барыбер ташны тишә.* Татарстан яшьләре

**Тамып яту** *сөйл. к.* **тамып тору**. *Ә менә диген бинаны кешечә саклый, куллана алмыйсыз: башыгызга су тамып ята.* Яңарыш

**ТАМЧЫ** *и.* **1.** 1) Сыек массадан аерылып төшкән яки атмосферада оешкан кечкенә генә шар формасындагы аерым өлеш. *Иртәнге чык тамчыларын эчеп, болынның хуш исләрен сулап, якты кояш җылыларында иркәләнеп пешкән шул ул, җанкаем!* Г.Бәширов. *Ананың күзләрендә көмеш яшь тамчылары җемелди иде.* А.Хәлим

2) Бик аз микъдарда сыеклык үлчәү берәмлеге. *Бер тамчы керосин, бер тамчы нефть әрәм ителмәс.* И.Гази. *Аның күзләре авырта, һәм ул ике күзенә ике төрле дарудан тамчылар тамыза иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Алка яки башка бизәнү әйберенең тамчы (*1 мәгъ.*) формасында

салынып торган бизәге. *Алтын алкалар колакта. Тамчылары көмешле.* Җыр

4) *күч.* Зур массаның кечкенәрәк өлеше. *Алай-болай шушы язганым аның игътибарына барып җитсә һәм бер генә миллиард доллар (аның өчен тулы чиләктән бер тамчы бит инде ул) китереп бирсә дә, Фәнзаман абыегызның йөрәге ярылуы ихтимал.* Ф.Баттал. *Халык – күл ул, ә күл тамчылардан тора, корымасын өчен, һәр тамчысы кирәк, һәр тере тамчысы кадерле.* Ә.Әминев

**2.** *с. мәгъ.* Бик аз булган, аз күләмдәге. *Аның яшь йөрәге хәтта әтисенә дә тамчы гаделсезлекне гафу итәргә теләми иде.* М.Маликова. *Тамчы яңгырның айлар буе төшкәне юк.* Р.Рахман

◊ **Тамчы бөртек** Аз, бик аз гына. *Бүген дин юлыннан китүемә тамчы бөртек тә үкенмим.* Ватаным Татарстан. **Тамчы да** Аз гына да; бер дә, бөтенләй. *Кызымны хастаханәдә калдырып чыктым. Аны ташлап киткәндә, йөрәгем ничек түздеме? Тамчы да борчылмадым.* Ватаным Татарстан

**ТАМЧЫГӨЛ** *и. к.* **тамчылы гөл**. *Тәрәзә төбендәге исле гөлләр, кыналар, тамчыгөлләр арасыннан өй эченә кереп, кичке чәен эчеп утыручы әбиләр колагын да рәхәтләндереп уза [ул].* Г.Бәширов. *Вилдан кулларын чалбар кесәсенә тыккан хәлдә түргә атлады, тәрәзә төбендә чәчәк атып утыручы тамчыгөлне иснәгәндәй итте дә тавышсыз адымнар белән кабат Әнвәрәнең каршына ук килеп басты.* Ф.Садриев

**ТАМЧЫЛАНУ** *ф. кайт. юн.* Тамчыга әйләнү, тамчы рәвешен алу; тамчыга охшаш булып китү

**ТАМЧЫЛАП** *рәв.* 1) Тамчы-тамчы булып, тамчылар рәвешендә. *Ул битенә, муеннарына кадәр тамчылап шыткан тирләрен сөртеп алды.* А.Хәлим

2) Тамчы-тамчы итеп, тамчылар белән үлчәп. --- *Аны юатыр, тынычландырыр өчен, тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.* Ә.Еники

3) *күч.* Аз-азлап, бөртекләп. *Син баш ватарга, сер белән очрашу ләззәтен тамчылап татырга җыенган буласың, ә монда...* А.Тимергалин. *Тормыштан алган тәэсирләрне, тамчылап җыелган яисә кинәт килгән фикерләрне кем беләндер уртаклашасы килә икән, бу бик табигый.* Р.Низамиев

**ТАМЧЫЛА́У** *ф.* 1) Тамчы-тамчы булып төшү. *Инде хәзер сырма итәкләреннән, җиң очларыннан туктаусыз су тамчылый.* Г.Галиев. *Әз генә вак яңгыр тамчылый.* Х.Камалов

2) *күч.* Тамчыга охшап күренү. *Кыпкызыл җиләкләр тамам-тамам дип тамчылап тора.* И.Салахов

**Тамчылап алу** Бераз тамчылау. *Шунда кыйшайган авызлы, селәгәйләре агып төшеп, идәнгә тамчылап алган берәү, почмакка сеңгән Кәримәне яклап, теге җәмкидәй кулларын сузып, гаҗизләгән кешеләрне читкә тибәрде, арысландай сугышырга теләп, аларга ташланып-ташланып куярдай сыман ыжгырынды.* Ф.Яхин

**Тамчылап тору** Даими яки әледәнәле тамчылау; әле, хәзер тамчылау. *Тамчылап торган салкын су астында токымны бораулап, штрекның түбәсен агач белән ныгытып, терәү салып куя.* Д.Каюмова

**Тамчылап утыру** *сөйл. к.* **тамчылап тору**. *Аның өстенә инде тузан куптарып җилләр искән, ул кар инде тыгызланган, ямьсезләнгән, көн-төн саркып, тамчылап утыра – бер кызыгы да юк.* М.Мәһдиев

**Тамчылый башлау** Тамчыларга тотыну. *Пеләшенә яңгыр тамчылый башлагач кына, Муссолини торышын ташлап, өенә таба атлады [директор].* Р.Газиз. *Күзләреннән аккан кайнар яшьләре борын очыннан ук тамчылый башлаган иде ---.* Ф.Яхин

**Тамчылый бирү** Бернигә карамый тамчылау. *Шулкадәр дә туфрак дымлы һәм җылы булгандыр инде, агач яфракларының очларыннан да су күз яшьләре кебек тамчылый бирде.* Ф.Яхин

**ТАМЧЫЛЫ** *с.* 1) Тамчысы булган; тамчылап төшкән. *Куе кара болытлар эченнән, гөрләтеп, эре тамчылы салкын яңгыр коя башлый.* Г.Ибраһимов. *Сездә ничек, бездә бүген Тамчылы яз балкышы.* Ә.Низамова

2) Тамчыга охшаш, тамчы формасындагы. *Кызым! Гөлләр таныйсыңмы? Тамчылысы – тамчы гөл! Фикус, яран, миләүшәне Истә калдыру җиңел.* Ф.Мәрдәнова

**ТАМЧЫЛЫ́ ГӨЛ** *и. бот.* Кырлыганчалар семьялыгыннан кызыл чәчәкләре аска таба салынып торган үсемлек, бүлмә гөле; тамчыгөл, фуксия. *Тамчылы гөл чәчәкләре кебек Күзләреңне түбән иясең ---.* Ф.Кәрим. *Тамчылы гөлнең хисапсыз күп алкалары көмештән коелгандай ялтырыйлар.* А.Гыйләҗев

**ТАМЧЫ́-ТАМЧЫ** *рәв.* **1.** Бер-бер артлы тамган тамчылар рәвешендә. *Өстәлләрдә шәмнәр яна. Тамчы-тамчы май тама.* Җыр. *Ак чыршының җептән юнылган ботак урыннарыннан, тамчы-тамчы булып, сары бал төсле пешек сытылып чыккан.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бик күп тамчылар рәвешендә булган. *Ян яктан урелгән чикләвек читәне башына җитәр-җитмәс төштә, аның түбәннән күтәрелүен шәйләп, матур, мул йөзен тамчы-тамчы тир баскан ире Котдус көтеп торган икән.* Ә.Гаффар

2) Бер-бер артлы төшкән тамчылардай. *Тамчы-тамчы сагыш яше Күздән түгел, җаннан тама.* И.Иксанова

**ТАМЫЗГЫЧ** *и.* 1) Сыеклыкның агым тизлеген чикләү, тамчылап салу өчен, бер очында тишеге булган көпшәсыман җайланма; пипетка. *Бала имезүче хатыннарның имчәк башы ярылган очракта, 4 –5 көн дәвамында тамызгычтан берничә тамчы каланхоэ сыгынтысын тамызалар.* Ватаным Татарстан. *Аңа марганцовка, тамызгыч (пипетка), марля, термометр һәм башка кирәкле әйберләр кирәк.* Авыл офыклары

2) Авыруларны дәвалауда даруларны кан тамырлары аша организмга тамчылап кертү өчен махсус җайланма; система; *русчасы:* **капельница**. *Кызны әлегә тамызгыч (капельница) аша тукландыргыч эремә белән туендырып торалар.* Ватаным Татарстан. *Ул баш тарткан очракта, дәва организмга инъекцияләр яки тамызгыч аша кертелә.* Туган як

**ТАМЫЗЛЫК** *и. диал.* Киптерелгән агач пүләненнән җепселләре буйлап

бик юка итеп телеп алынган кисәк, бик юка агач телеме, чыра

**ТАМЫЗУ** *ф.* 1) Бер тамчы төшерү яки тамчылап, аз-азлап кына салу, агызу. *Агач ботаклары артыннан беребез сәхнә идәненә кызыл кара тамыза.* М.Мәһдиев. *Көн саен иртә-кич менә шушы рецепт белән алган даруны тамызырсыз...* А.Тимергалин

2) *күч.* Бераз исерткеч эчемлек эчү. *Ыһы, мин әйтәм, коньякны ярыйсы тамызган ахры бу.* Ф.Яруллин. *Ир-ат та тимердән түгел, түзми: тамызып кайтырга өйрәнә.* Д.Алмазова

3) *күч.* Беркадәр ришвәт я әҗер бирү. *Һәм чыннан да, әгәр икесе дә йөзәр сум тамызган булмасалар, чынлап та кеше арасына исемнәрен чыгарачак идем, ярый әле бүген котылдылар.* Г.Камал. *Кул куйган саен өч йөз сумны тамызсалар, мин имзамны, беләсеңме, кайларга куяр идем!* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Бераз гына, аз күләмдә өлеш чыгару, бирү. *Ходай Тәгалә икесенең берсенә, бәлки, талант орлыгы тамызгандыр.* Н.Әхмәдиев. *Кыскасы, безнең бюджет мәгърифәткә, аеруча әдәбиятка, сәнгатькә һәм фәнгә дигән акчаны бармаклары арасыннан кысып кына тамыза.* Ә.Еники. *Бигрәк тә тормыш үзенең барча нигъмәт-ганимәтләрен берәүләргә йөк-йөк бирә, ә икенчеләргә тамчы да тамызмый.* Х.Камалов

5) *күч. гади с.* Кешегә яки башка берәр җан иясенә бик каты сугу. *Аюаю егерме егетнең һәркайсына Усман урядник үзе камчы белән икешәр тапкыр тамызды.* А.Шамов. *Хатыны утыруга, колхозлашканчы үзләренеке булган кашка айгырга Гыймади чыбыркы белән тамызды.* Н.Әхмәдиев

6) *күч.* Әләкләү, сүз җиткерү

7) *күч.* Берәр кешегә ниндидер фикерне әйтеп кую, белгертү; үз фикерен үткәрү өчен гел әйтеп тору

**Тамыза бару** Билгеле бер вакыт дәвамында эзлекле рәвештә тамызу

**Тамыза башлау** Тамызырга тотыну. *Сестра наркоз сыекчасын яралының борын турына марляга тамыза башлады.* Х.Камалов. *«Юбилейларны үткәрү – бик файдалы һәм кирәкле шәйдер»леге турында әкрен-әкрен генә фикерләреңне сыек милеләргә тамыза башлыйсың.* М.Галиев

**Тамыза тору** Һаман тамызу. *Шулай тамыза торгач, котырта торгач, бер елны бу, әйтелгәнчә, мине алып, үзенең Янтыгына кайтып киткән.* Н.Фәттах. *Авыр сынау мизгелләрендә дә мәңгелек тереклектә өзеклек була алмый, хәят, берни белән санашмыйча, үз канунnарын куа, дөньяга көрәшчеләрнең дәвамчыларын китереп, кендек каннарын җиргә тамыза тора.* Т.Галиуллин

**Тамыза төшү** Бераз тамызу; тагын да күбрәк тамызу

**Тамызып алу** Тиз генә тамызу; аз гына тамызу. *Ул пәһлеван ирләрдәй калын тавыш белән командирларча кискен итеп сөйләшә, кызып киткән чакларында каршы әйкәннәргә чыбыркысы белән тамызып алырга да күп сорамый, имеш.* М.Маликова. *Кеше күрмәгәндә, завхоз абый бер-ике тапкыр җилкә тамырына тамызып та алды әле.* И.Диндаров

**Тамызып бетерү** Күп итеп тамызу; кирәкле кадәр тамызу

**Тамызып җибәрү** Кинәт тамызу; нәрсәдер өстенә өстәмә рәвештә тамызу. --- *өч-дүрт тамчы гына маен тамызып җибәрсәк, бер километр түбәндә йөзгән балык та аның тәмен тоеп, кормушка төбенә атыла.* Казан утлары

**Тамызып йөрү** *к.* **тамызып тору**. *Ә Каюм Салахович, заемны киметү өчен, мәзингә садака тамызып йөри.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тамызып кую** Алдан тамызу. *Җае чыкканда ялагайларга шәбрәк тә тамызып куя ул.* Ф.Яруллин. *Чәй эчкән чәшкесенә бер-ике тамчы сихерле су тамызып куйса, ләхәүлә.* К.Кара

**Тамызып тору** Әледән-әле яки берөзлексез тамызу; хәзер тамызу. *Хәзергә күзеңә «Смирнов тамчылары» тамызып тор.* Ф.Хуҗин. *Ә «җан сакчысы» үзенең нечкә көпшәләреннән Бибисага берөзлексез ниндидер дарулар тамызып тора.* Казан утлары

**Тамызып утыру** *сөйл. к.* **тамызып тору**. *Мәңге яшел наратлар еллар буе хуш ис бөркиләр, бал-сагыз тамызып утыралар.* Р.Баттал

**Тамызып чыгу** Барысына да тамызу. *Ашый башлаганчы, Дәүләтгәрәй абзый, иелеп, өстәл астыннан бер шешә ак аракы алды да башта үз рюмкасына салды, аннан соң яшьләр алдындагы рюмкаларга тамызып чыкты.* Н.Фәттах. *Иртән торгач, урын җыю, мендәр атышу йоласы башлана һәм ул Фатих хәлфә, сакалсыз саргылт йөзен чалшайтып, тал чыбыгы белән шәкертләрнең аркасына чажылдатып тамызып чыкканчы дәвам итә.* Казан утлары

**ТАМЫЗЫМ** *и.* Бер тапкыр тамызырлык күләм, бер тамчы күләме. *Шешә төбендә бер тамызым дару калган*

**ТАМЫР** *и.* **1.** 1) Үсемлекнең туфрактан су, минераль матдәләр суыра торган, җир астына урнашкан өлеше. *Урманда, болыннарда хәзер яфрак, яшь үрентеләр, сутлы кайры, ашарга ярарлык үлән тамырлары, суда балык бар, һич югы бака бар; кырда чыпчык, карга, күгәрчен, чәүкәсе бар.* М.Галәү. *Әти, кара әле, суганны тамырлары белән саталар.* Р.Миңнуллин

2) Үсемлекләрнең тамырларын кайнатып, төнәтеп ясалган сыек дару. *Ичмаса ясаган тамыр әрәмгә китмәсен, кемгә булса да икенче бер кешегә бирермен.* Г.Камал. *Гөлҗиһан әби миңа үлән тамыры бирде, менә, шуны эчкәч, иртә уяндым...* А.Гыймадиев

3) Кайбер әгъзаларның тәнгә кереп үскән өлеше. *Аңа теш тамырыннан инфекция кергән.* М.Маликова. *Мәрьямбануның чәч тамырларыннан алып аяк бармакларына кадәр яшен уты үтеп киткәндәй булды.* Ф.Бәйрәмова

4) Кеше һәм хайваннар организмындагы кан йөрү каналлары. *Биктаһир зәңгәр тамырлары бүртеп чыккан ябык, соры кулын яшь чыгып торган күзләре өстенә куеп, ниндидер шыгырдавык тавыш белән сорады.* И.Гази. *Алар кулында ниләр татыганын Азат җәелеп сөйләмәде, бу вакытта аның агарынган яңакларында каты төерләр йөргәнне, бүрткән чигә тамырлары ничек типкәнне күреп, мин дә артык сорашасы итмәдем.* А.Тимергалин

5) Сеңер. *Карт, исерек вакытта тимер аршын белән сугып, Хәлимәнең җилкә тамырын өзгән.* Ш.Камал. *Идән юу, кер уу, бер карасаң, авыр эш тә түгел, әмма Рөстәм шыбыр тиргә*

*батты, йөрәге дарслап типте, муен тамырлары тартышып-тартышып куйды.* М.Кәбиров

6) *лингв.* Сүзнең реаль мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге; сүзнең этимологик нигезе. *Татар телендә һәрбер тамыр аерым сүз була ала һәм конкрет сүз төркеменә карый...* Д.Тумашева. *Г.Алпаровның «Татар теленең имля сүзлеге» (Казан, 1927) «эш» тамыры кергән байтак кына сүзләрне туплаган.* А.Тимергалин

7) *мат.* Билгеле бер дәрәҗәдә кыйммәте күрсәтелгән, үзен хисаплап табарга кирәк булган сан. *16 ның дүртенче дәрәҗә тамыры – 2.* Математика

8) *мат.* Тигезләмәнең чишелеш нәтиҗәсе. *Тигезләмәне чишү – аның барлык тамырларын табу яки аның тамырлары юк икәнне исбатлау ул.* Алгебра

9) *күч.* Минераль токымнарның тармак-тармак булып формалашкан ятмасы. *Ташта --- бармак юанлыгы алтын тамырлары күренеп торалар иде.* М.Гафури

10) *күч.* Кабель эчендәге бер-берсеннән изоляцияләнгән үткәргеч чыбыкларның һәрберсе. *Кабель җиде тамырлы бакыр чыбыктан тора*

11) *күч.* Берәр вакыйганың, иҗтимагый күренешнең тирән сәбәпләре, бәйләнешләре. *«Таулар»да корткычлар зур бер коллективка каршы көрәш алып баралар, һәм әсәрдә бу көрәшнең тарихи тамырлары да пролог рәвешендә күрсәтелеп бирелгән.* Г.Нигъмәти

12) *күч.* Берәр нәрсәнең беренчел яралгысы, билгеләре, башлангычы. *Адәм җанында менә шулай мин-минлек тамырларын шактый тирән җибәреп, чәчәкләр атып утыручан бит ул.* Ф.Яхин

13) *күч.* Кешенең ата-бабасы, чыгышы, нәсел-ыруы. *Ялчылар белән минем арага кереп, нәселнең йөзенә кара ягып килгән кыз, бүген бер көтүчегә төшәчәк таякны да үзенә йөкләп, ак нәселнең тамырын черетте.* М.Фәйзи. *Нәселебезне, җир-суларыбызны, тамырыбызны оныттырмый торган изге җыр бу...* А.Тимергалин

14) *күч.* Туган-тумача, кардәш-ыру, нәсел-нәсәп. *Сөйлә, укучыларым, дусларым, Тамырларым минем исәнме?* Ф.Бурнаш

15) *күч.* Кеше характерының көтмәгәндә-уйламаганда ачыла торган бер сыйфаты. *Шапырынма, иптәш Дубровский, Сафаровның бүген шаяру тамырлары кузгалган.* Ш.Камал

16) *күч.* Нигез, башлангыч; асыл. *Бөтен дөньядагы телләр өч тамырга кайтып кала вә шуңа күрә башлап өчкә бүленәләр.* Җ.Вәлиди. *Ачу килү – көнчелекнең тамыры ул, дигән имам Газали.* Ф.Яхин. *Дөньяда бөтен нәрсәнең тамыры бар.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төп, үзәк. *Бу чишмәләр үзләренең көчен әлеге үзәк, тамыр чишмәгә биреп тора кебек...* Г.Гыйльманов

2) *лингв.* Реаль мәгънәгә ия булган, кушымчалардан башка булган (сүзнең төп өлеше тур). *Сүзнең ясалма булуы тамыр сүзгә каршы куелып билгеләнә...* Д.Тумашева. *Чыннан да, әйтик, төрек теле төрки телләр арасында иң күп таралганы булса да, ул гомумтөрки типтан ераграк тора, ә татар телендә тугандаш телләр белән уртак тамыр сүзләр проценты күбрәк.* А.Тимергалин

◊ **Тамыр җәю** Ныклап урнашу, таралу, көчәю. *Элек ул теория бик тирән тамыр җәйгән иде.* А.Алиш. *Карткорылар үзләренең туган нигезләрен сагынып кире әйләнеп кайтмаслык дөньяга юл тоттылар. Бары тик бернičә гаилә генә Ташлыярда тамыр җәйде.* Ф.Яруллин. **Тамыр җибәрү** Төпләнеп калу, урнашу; таралу. --- *Аллаһ тыйган тагы бер гамәл бик тирән тамыр җибәргән: ул – ришвәтчелек, ягъни взятка алу һәм бирү.* Ф.Бәйрәмова. *Кызык, алар бирегә – кояш баешына – каян килгәннәр дә ничек шушында төпләнгәннәр, тамыр җибәргәннәр икән?* А.Тимергалин. **Тамырларга таралу** Исерткеч эчемлекләр яки берәр бик кайнар азык, эчемлек көчле тәэсир итү. *Мәгәр карт озак көттермәде, кымызның куәте тамырларга таралып, канны бераз кайната башлау белән, үзе серне ачты: – Атаң мәрхүм белән якын дус идек... Кызым Чулпан исән торса, киявем булачак идең; шулай булса да, мин бу җәйләүгә кунак булып килмәдем, – диде.* Г.Ибраһимов. **Тамыры белән йолку** Тулысынча юк итү; бөтенләй оныттыру *Менә ни өчен безгә Аллага табынуны җимерергә, --- аллачылык һәм рухилык принцибын тамыры белән йолкып алырга һәм аны арифметик исәп-хисаплар, материаль ихтыяҗлар белән алыштырырга кирәк.* М.Кәбиров. **Тамыры кору** Юкка чыгу, бетү, таркалу. *Тамырың корымаса, барыбер күтәрелеп чыгасың.* Ф.Яхин. *Казан-йорт та шул хәлдә, чөнки аңа нигез салган Олуг Мөхәммәд нәселенең тамыры корыды.* М.Әмирханов. **Тамырына балта чабу** Берәр нәрсәгә зур зыян китерү, төптән җимерү, юк итү, үсешен туктату. *Син каныма, мигә, геннарыма Моңлы аваз итеп кертелгән. Тамырларга балта чабылса да, Өзелмичә калган җепләр без.* Г.Сабирова. *Икенчедән, сез совет властеның тамырына балта чабуда гаепләнәсез.* З.Мурсиев. **Тамырына су сибү** Читтән торып бик зур ярдәм итү. **Тамырына су сиптеләрмени** Бик тиз үсеп китү, алга китү турында. *Олы башлы, тәбәнәк кенә малай булып йөрде-йөрде дә, тамырына су сиптеләрмени, соңгы ике елда Җәүдәт бик нык калкынып китте, берсендә тугыз, икенчесендә унбер сантиметрга күтәрелде.* А.Гыйләҗев. **Тамырына су сипкән кебек** *к.* **тамырына су сиптеләрмени**. **Тамырын йолку** *к.* **тамырын корыту**. **Тамырын корыту** Нәселен, чыганагын, башлангычын бетерү. *Күңелләрендә дөреслек, намус хисен йөрткән кешеләрнең авылда күптән тамырлары корытылганлыгын әлегә һаман да белми яши.* Ф.Яхин. **Тамыры тибү** Җанланып китү, үсеш алу

**ТАМЫРАВЫЗ** *и. зоол.* Эчәккуышлылар классыннан кармавычлары һәм беренчел авызы булмаган, авыз кырыйлары күпсанлы авыз тишемнәре урнашкан тамырдай «куллары» белән тоташып киткән медуза; *русчасы:* **корнерот**. --- *тамыравыз, медуза, актиния, физалия (Португалия корабчыгы) тирене чагалар һәм температура күтәрелү, агулану --- китереп чыгаралар.* Биология

**ТАМЫРАЗЫК** *и.* Кирәкле азык матдәләре тамырының төп өлешенә җыела торган авыл хуҗалыгы культурасы.

*Безгә күп итеп үлән чәчәргә кирәк, күп итеп тамыразык чәчәргә кирәк.* Ә.Еники. *Юньле азыктан тәмам бизгән эчләребез чи тамыразыкны өнәмәде: борып авырта башлады.* Ф.Хуҗин

**ТАМЫ́РАСТЫ** *и. мат.* Тамыр (радикал) билгесе астына язылган сан. *Алгебрадан тамырасты турындагы дәрестә мин шул төшенчәне аңлата гына алмыйм бит.* Ш.Алпар

**ТАМЫ́РАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Үсемлек тамырын хәтерләткән ялганаяклар ярдәмендә хәрәкәтләнүче иң гади төзелешле организмнар классы; *русчасы:* **корненожки**. *Тамыраяклылар диңгез суында һәм төче суда, туфракта, башка организмнарда яшиләр.* Биология

**ТАМЫ́Р БЕТЕ** *и. зоол.* Гөбләләр семьялыгыннан үсемлек тамырларын зарарлаучы вак бөҗәк; *русчасы*: **корневая тля**; **корневой клещ**. *Тамыр бете гөлләрне дә зарарлый*

**ТАМЫРДАН** *рәв.* Төптән үк, нигездән; катгый рәвештә, кискен. *Бу фактор мәсьәләне тамырдан үзгәртә бугай...* А.Тимергалин

**ТАМЫРДАШ** *с.* **1.** 1) Бер тамырдан үсеп чыккан. *Тамырдаш куаклар*

2) Бер милләткә, ыруга, нәселгә караган, туган. *Әхсән туган, тамырдаш ла син!* Казан утлары

3) *лингв.* Бер тамырдан ясалган. *Шуны да әйтми булмый: тышкы охшашлык яисә мәгънә бәйләнеше ягыннан килеп, теләсә нинди ике сүзне бердәй дип яки тамырдаш дип карау һич кенә дә ярамый.* Р.Әхмәтьянов

4) *мат.* Бердәй тамырга ия булган. *Ике тигезләмәнең тамырлары бер төрле булса, алар тамырдаш тигезләмәләр дип аталалар.* Алгебра

5) *күч.* Бер дәрәҗәдәге, бер үк төрле бәяләнә торган. *Ялган – явызлык белән тамырдаш.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Кавемдәш, ырудаш, милләттәш. *Тотыш би үзе, иле-көне, ырудашлары, тамырдашлары Болгар ханнарының якыны, ышанычлы таянычы булсын, мине дошманнардан көч белән, байлык белән якласын ---.* Н.Фәттах

**ТАМЫРЛАНУ** *ф.* 1) Тамыр җибәреп туфракка, җиргә берегеп китү, үсә башлау (үсемлекләр тур.). *Ике кат эшкәрткәч, чөгендер, ниһаять, чүп үләннәрен узып китте, каракучкыл яшел яфракларын җәеп, юан тамырланып ныгыды.* Г.Якупова

2) *күч.* Берәр урынга озакка урнашып, шунда яшәү, төпләнү. *Кайсы кыйтгага төпләнеп тамырланса да, безнең кавем бәрәкәтле яшәргә омтыла.* Казан утлары

3) *күч.* Кайда да булса танылу, абруй казану. *Яңа эштә тамырланып өлгерү*

4) *күч.* Берәр күренеш таралу, киңәю. *Шуңа күрә «кайтканнар» гына зур авылның төп тормыш көен әллә ни үзгәртә алмадылар, чөнки аның борынгыдан килгән гореф-гадәтләре нык тамырланган иде.* З.Хөснияр. *Ихтыяр көче үз-үзеңә һәм мөмкинлекләреңә ышанудан туа, ныгый, тамырлана.* Р.Низамиев

**Тамырлана бару** Торган саен ныграк тамырлану. *Ләкин бер-берсе өстенә өелгән бу күп сораулар хатынның йөрәген җиңә алмады, ул үзенең күңелендә туган яңа ышанычы тагы ныграк тамырлана барган кебек сизенде.* Г.Ибраһимов. *Герой шагыйрь үлеменә күп еллар узса да, аның каһарманлыгы халык күңелендә ныграк тамырлана гына бара.* Кызыл таң

**Тамырлана башлау** Тамырланырга тотыну. *Радиотыңлаучылар белән элемтәләрне ныгыту юнәлеше шулай ук нәкъ менә шул елларда тамырлана башлады.* Ж.Дәрзаман. *Феодаль торгынлыкка, самодержавиегә, крепостнойлык калдыкларына, туып килә торган капиталистик мөнәсәбәтләргә каршы юнәлдерелгән халыкчылык хәрәкәте Россия җирлегендә XIX йөзнең уртапарында тамырлана башлый.* Р.Ганиева

**Тамырлана килү** Күптәннән бирле акрынлап тамырлану. *Әдәби үсентеләр әнә шул рәвешле, күкрәп үсеп китәргә уңайлы шартлар булмау сәбәпле, халык рухы тирәнлекләреннән, аның өметхыялларыннан үзенә яшәү суты эзләп тамырлана килгән.* М.Хәсәнов

**Тамырлана төшү** Бераз тамырлану, тагын да ныграк тамырлану

**Тамырланып бару** *к.* **тамырлана бару**. *Бик тамырланып бара әле бу лейтенант кисәге.* С.Рафиков

**Тамырланып бетү** Тәмам тамырлану. *Без инде, оланнар, авыл җиренә ияләшеп, тамырланып беткәнбез.* Р.Низамиев

**Тамырланып җитү** Тиешле дәрәҗәдә тамырлану. *Кичә әле Мостафаны каплаган бу кара фикер тамырланып җитмәгән.* Ф.Әмирхан

**Тамырланып килү** Акрынлап тамырлану. *Ул да булса, татар җирлегендә тамырланып килгән капиталистик мөнәсәбәтләрне кабул итмәү, авылларын ташлап, шәһәргә яллы хезмәткә килүче ирләрнең, аеруча хатын-кызларның, әхлаклары бозыла дип санау.* Р.Ганиева. *Үткәннән үк тамырланып килгән традицион татар прозасын, шигъриятен укучы өлкән буын әле дә исән ---.* Казан утлары

**Тамырланып китү** Тора-бара тамырлану; тагын да ныграк тамырлану. *Я, аның дым эчкән туфрак шикелле сагыш белән тулы йөрәгенә нинди генә орлык төшсә дә, ул тиз генә тамырланып китмәс идемени?* Ә.Еники. *Төпләнеп, тамырланып китсәгез, Күкчәтау авыл хуҗалыгы институтына керерсез.* А.Хәлим

**Тамырланып тору** Әле, хәзерге вакытта тамырлану. *Агач дигәч, мин эшче кешенең – эшсояр кешенең – тамырланып торган кулларын күз алдына китерәм!* А.Гыйләҗев

**ТАМЫРЛЫ** *с.* 1) Тамырлары булган; тамырлары күренеп торган. *Тик Мәрхәмбикә, нәрсәдер сизенгәндәй, бер дә кабаланып тормый, таза тамырлы агач кебек, кыймылдамыйча утыра бирә.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Ышанычлы, дәлилле, нигезле. *Ирония юкка, сэр, барысы да тамырлы, архивтан...* Г.Каюмов

3) *күч.* Рәтле, төпле. *Ары сугыла, бире бәрелә дә төпле, тамырлы бер эш майтара алмыйча үлеп тә китә --- [андый кеше].* Р.Батулла

**ТАМЫРЛЫК** *и.* Агач һәм куакларның тамырлары күп итеп җир өстенә чыгып торган урын. *Менәр идем – тау биек. Төшәр идем – тамырлык.* Җыр

**ТАМЫР-ТОМЫР** *җый. и.* Һәртөрле үсемлек тамырлары. *Селкенә алган карт-корыга, бала-чагага да эш табылды: алар көрәк, балталар ярдәмендә ак-*

*тарылып чыгарылган тамыр-томырны, агач черекләрен җыеп-чүпләп, янган учакка ташып тордылар.* М.Хәсәнов. *Утрауда чәйлек мәтрүшкә, гөлйөзем яфрагы, төрле тамыр-томыр кебекләр җитәрлек иде.* Т.Нәбиуллин

**ТАМЫРЧА** *и.* 1) Вак тамыр. *Гөлнең тамырчалары арткан*

2) Күпьеллык үлән үсемлекләрнең бөреләр, өстәмә тамырлар, вак яфраклары булган, азык матдәләре туплау һәм вегетатив үрчү өчен хезмәт итә торган җир асты бәбәге; *русчасы:* **корневище**. *Яфраклар тамырчадагы бөреләрдән үсеп чыга һәм җир өстендә ачыла.* Биология. *Бу үсемлек орлыкларыннан һәм вегетатив юл белән – тамырчаларыннан үрчи.* Әлмәт таңнары

3) *куч.* Нәсел дәвамчысы; туган. *Үз каны, үз тамырчасы икәнен белә торып баласыннан ваз кичкән адәмнәр күпме җир йөзендә?* Р.Мулланурова

**ТАМЫР ЧИРЕ** *и. мед.* Кан туберкулёзы. *Фазулланы нindидер тамыр чире белән авырый дип әйтәләр.* Г.Бәширов

**ТАМЫРЧЫК** *и.* Орлык шытканда, орлык кабыгыннан иң элек килеп чыга торган тамырның башлангыч өлеше. *Яралгы тамырчыгы да, зур үсемлекнең тамыры да, башка барлык органнар кебек үк, күзәнәкчел төзелешле.* Биология. *Бәрәңгене якты, җылы, дымлы урында үрдерү отышлы, чөнки алар нык була, тиз арада тамырчыклар һәм яшел яфракчыклар җибәрә.* Безнең гәҗит

**ТАМЫРЫННАН** *рәв. к.* **тамырдан**. *Тәмам аптырагач, йөдәгәч, Мәхмүтнең агасы беркөнне бу эшне тамырыннан өзәргә уйлаган.* Н.Исәнбәт. *– Тел төбегезне аңладым, – диде Марсель, – Буләкшадбикәне Сөембикә белән тиңләштерү тамырыннан дөрес түгел.* М. Әмирханов

**ТАНА** *и.* **1.** 1) Ике яшен тутырган теше бозау. *Зур өмет баглап саклап торган тананы салым өчен алып чыктылар.* М.Галәү

2) Гомумән сыер, сыер малы. *Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берне дә бозауламаган, яшь. *Тана сыер җиленләгәндә белми, бозаулаганда белә.* Мәкаль

2) Теше, инәк. *Берсе үгез, икенчесе тана бозау...* Р.Батулла. *Иң гади авыл арифметикасы: ике сыерга ике бозау, узган елгы бер бозауны иткә суялар, бер тана бозау нәселгә калдырыла, киләсе елга бозылыбрак киткән сыерны суеп, әлеге башмакны савымга куялар.* Г.Гыйльманов

**ТАНАКОЛАК** Зур, тырпаеп тора торган колаклы кеше. *Тезләнеп кичерүемне сораячаксың, тана колак!* Р.Сәгъди

**ТАНА́У** *и.* 1) Хайван башының очлаеп торган борын өлеше. *Танавыннан алып колагына кадәр көлгә баткан бозау рәхәтләнеп күләгәдә ята ---.* Ф.Садриев. *[Бүре балаларының] Башлары зур, тәпиләре озын, танаулары очлы.* А.Хәсәнов

2) Гомумән хайваннарның борыны. *Этнең танавына типкәннәр.* Ш.Галиев

3) *диал.* Кеше борыны. *Кияү кеше танау, колак, тамак чирләре буенча белгеч иде.* К.Кара. *Лупа сыман калын пыялалы күзлекле, малайларныкы кебек кыска, буялган кызыл чәчле, торнаныкыдай озын ботлы, танавына алка кигән, күн итәк, курткадагы бу кызның исеме Эля икән.* Ф.Хәбибуллин

◊ **Танавына масаю** Үзенең тышкы кыяфәте белән сәбәпсезгә эреләнү, масаю. *Арада яшьлегенә, танавына масаючылар да буладыр иде.* Ф.Хөсни. **Танавын җимерү** Кыйнау, биткә йодрыклап сугу. *Авыру булмасаң, бу сүзең өчен танавыңны җимерә идем җимерүен, шул авыру булганга гына, кулымны пычратып торасым килми.* В.Нуруллин. *Танавын җимерергә дә хакы бар капитанның!* С.Шәрипов. **Танау астында** Бик якында, борын төбендә. *Уяулык җитми, иптәш лейтенант: Алкинда, Таутөмәндә бергә булган, адым саен танау астыгызда йөргән яугирнең дә кем икәнлеген, эчке дөньясын белмисез!* С.Поварисов. **Танау асты кипмәгән** Балигъ булмаган, яшь; тәҗрибәсез. *Нәрсә син, танау астың кипмәс борын, егетләр эшенә тыгыласың!* Г.Бәширов. *Казан тәхетенә Касыйм ханы, аның танау асты да кипмәгән туганы Җангали тәгаенләнгән, имеш.* М.Әмирханов. **Танау белән җир сөрү** Бик күп, авыр эш эшләү. *Йөри хәзер менә ялгыз танавы белән җир сөреп.* Р.Рахман. **Танауга берне салу** Сугу. *– Бар, Сәкинә, йөгер! – дидем дә, кизәнеп торып, теге егетнең танавына мин дә берне салдым.* В.Нуруллин. **Танауга төкерү** Мыскыллы рәвештә санга сукмау, ис китмәү. *[Әпипә:] – Ай, кәбәм, кирәкми! Төкер тunion танауларына! – дип, аны [Зиннәтне] читкә таба алып китте.* Г.Бәширов. **Танауга чиртү** Нинди дә булса эштә, өлкәдә икенче бер кешене уздыру. *– Бәй, шулай булмый ни, без әллә нинди мачтырларның да танавына чиртәбез, – дип масайды Шәвәли.* С.Рафиков. *Син Валерий сумкасыннан ачкычны алып безгә тапшырсаң, шул мактанчыкның танавына чиртер идек!* А.Гыйләҗев. **Танау киерү** Масаю, эреләнү. **Танау күтәрү** *к.* **танау киерү**. *Күтәрмә танавыңны, кара канга манчый идем...* А.Гыйләҗев. **Танауны салындыру** Күңелсезләнү, боегу; үпкәләү, канәгатьсезлек белдерү. *– Хәлләр бик тә хөрти, – ди танавын салындырган, иренен сәлендергән Көнчел.* А.Хәлим. **Танауны бору** Баш тарту, кирәксенмәү, йөз чөерү. *Бабайлардан танавыңны борма Шигырь мәйданында ярышта.* Г.Афзал. **Танауны чөйгә элү** Үзен әллә кемгә санау. *Әз генә артык җире булса, танавын чөйгә элә башлый адәм баласы.* К.Кара. **Танау төшерү** Күңелсезләнү. *Берәү булса, танавын төшереп кайтып китәр иде, Рәмзи андыйлардан түгел.* Кызыл таң. **Танау чөю** Бик масаю, кукраю. *Мондый күңелле киләчәктә Дамирга бик бәләкәй, бик кысан урын калдырган идем мин: танавыңны чөеп, хат язарга иренеп йөргән идеңме, мә сиңа!* А.Гыйләҗев. *Танавыңны чөеп йөрмә әле!* Л.Лерон. **Танау яру** Ис бик каты аңку, көчле тәэсир итү. *Танауларны ярырлык тәмле, хуш бал исләре аңкый.* М.Гафури. **Танау ярып керү** *к.* **танау яру**. *Ишек төбеннән үк тәмле исләр танауны ярып керде.* К.Кара

**ТАНБУР** *и. фар.* Декасы груша формасында булган озын саплы кыллы музыка коралы; сазның бер төре. *Җәгъфәр ишан үтә зур осталык белән Хөрәсән танбурында (төрки танбурда) уйна-*

*ган һәм үзенең сәнгатенә мөритләрен дә өйрәткән.* Г.Макаров. *Думбра, дәф, танбур, сызгычлар татар халкына яңадан кайтты.* Туганайлар

**ТАНБУРЧЫ** *и.* Танбурда уйнаучы. *Чаңчеләр һәм танбурчыларның дәртле аһәңенә кушылып, Елантау өстен янә йөзәрләгән яугирләрнең шатланып кычкырган тавышлары күмде ---.* В.Имамов

**ТА́НГЕНС** *и. лат. мат.* Тригонометрик функция – турыпочмаклы өчпочмакта кысынкы почмакка каршы яткан катетның икенче катетка чагыштырмасы. *Синус, косинус, тангенс, котангенс, дип кабатлап, баш ватып утыра [ул].* А.Хәсәнов. *Тангенс вакланмалы функция икәне һәм вакланманың хәсыйләсен тапканда, җавапта иң элек аның ваклаучысын (косинусның квадратын) язарга кирәклеге өйрәтелмәгән ---.* Фән һәм тел

**ТА́НГО** *и. исп.* 2/4 өлеш үлчәмендәге, уртача темптагы пунктир яки синкопалы ритм формуласындагы бию төре; шундый бию өчен язылган көй. *Ә менә матросский клуб яки паркка барып кергәч, шул малайлар, ленталарын җилфердәтеп, фокстрот, танго, вальс биеп җибәрәләр ---.* М.Мәһдиев. *Без ризыкларга кагылмадык та, берберебезгә сыенып, әкрен генә танго биедек.* Н.Гыйматдинова

**ТАНДЕМ** *и. ингл. махс.* 1) Әйберләрне бер-бер артлы урнаштыру тәртибе. *Тандем тибындагы мәйданчыклар*

2) Ике урынлы велосипед. *Тандемда йөрү*

3) Бер команда булып чыгыш ясаучы, эшләүче ике кешенең, оешманың берлеге. *Әлегә тандем бу темага ачыктан-ачык үз фикерен ирештермәде.* Кәеф ничек? *Әлеге тандем безне һәрвакыт хит җырлар белән сөендерә.* Хезмәт даны

**ТА́НЕЦ** *и. нем.* 1) *иск.* Халык биюләреннән аермалы буларак заманча яки классик бию. *Хәзерге танец – биюләр турында әйткән дә юк.* М.Шабаев. *Уртага чыкты да [ул]: «Мин ак танец игълан итәм!» – дип белдерде.* С.Зыялы

2) Гадәттә биюләргә багышланган кичә яки шуның бер өлеше. *Хәят, Әминә вә Рәсимә абыстай да бер рәттәрәк тезелеп утырганнар, музыка вә танецлар көтәләр иде.* Ф.Әмирхан

**ТАНИН** *и. фр.* Агач кайрысыннан, тамырларыннан, өлгереп җитмәгән җимешләрдән, чәй, кофедан алына һәм медицинада, тире иләүдә кулланыла торган сары матдә. *Чәйләрдә танин һәм башка шундый файдалы матдәләр, эфир майлары булуы да безгә билгеле.* Татар халык ашлары. *Танин исә бик яхшы абсорбент, ул әгъзалар һәм тамырларның тышчаларындагы зарарлы матдәләрне үзенә сеңдерә.* Мәдәни җомга

**ТАНК** I *и. ингл.* Эре калибрлы корал белән тәэмин ителгән, чылбыр тәгәрмәчле, бронялы үзйөрешле хәрби машина. *Финляндия өстендә очкан самолёт тавышлары, меңләгән корыч танклар авазы бөтен Скандинавия ярыматавын тетрәтеп, Европа илләренә барып ишетелә.* Т.Гыйззәт. *Кайдадыр танклар үкерә, самолётлар гүли, командирлар кычкыра, җир ухылдый...* Г.Гыйльманов

**ТАНК** II *и. ингл.* Сыеклыклар салып ташу яки саклау өчен җиһазландырылган махсус резервуар, цистерна

**ТА́НКЕР** *и. ингл.* Махсус зур резервуар – танкларда сыек йөкләр ташый торган судно. *Без, сабый балалар кебек, бөтен дөньябызны онытып, күгәрченнәр, песнәкләр, урам чыпчыклары һәм тагын әллә нинди кошлар белән әйлән-бәйлән уйнадык, бихисап пароходлар, ракеталар һәм йөк төялгән танкерлар йөзгән Идел елгасында хәлдән тайганчы су коендык.* З.Мәхмүди. *Ул да булмый, зур-зур әрҗәләр, танкерлар, кораблар янәшәсендә шырпы кабы сыман кечерәеп калган дебаркадер каршына яртылаш суга сеңгән пароход килеп туктый.* В.Имамов

**ТАНКЕ́ТКА** *и. рус* 1) Пулемёт белән коралландырылган бер-ике кешелек җиңел танк. *Ә юлдан сугыш ягына таба безнең бәләкәй танклар (танкеткалар) килә иде.* Р.Могыйнов. *Солдатларның сөйләве буенча, техника күп булмаса да, ике авыр танк, бер танкетка, шактый гына атлы артиллерия була.* З.Мурсиев

2) Үкчәгә таба калынаеп килгән олтанлы җиңел җәйге аяк киеме. *Клара, ниһаять, торып, киң билбаулы ефәк халатын гына киеп һәм яланаякларына ак танкеткаларын элеп, чоланнан чыкты.* Ә.Еники. *Аякта тишек-мишек танкетка.* Н.Фәттах

**ТАНКИСТ** *и. рус* Танк гаскәрләре хәрбие, танк экипажы әгъзасы. *Танкистлар, люкларын ябып, танкларына утыралар...* Г.Әпсәләмов. *Танкист өчен иң кулай урын танк эчендә инде.* И.Хуҗин

**ТАНКИСТЛЫК** *и.* Танкист хезмәте, танкист булу. *Шуңадыр танкистлыкка укыттылар мине.* Р.Низамиев. *Ләкин, буең озын дип, аны танкистлыкка алмыйлар.* Безнең гәҗит

**ТАНКОДРОМ** *и. рус* Танк йөртергә өйрәнү, танкларны сынау өчен махсус мәйдан. *Чыннан да, танк паркында туктаусыз техника чистарту, иске буяуны кыру яки полигонда, танкодромда көн-төн туңып йөрү җиңел түгел иде.* И.Хуҗин

**ТА́НКЧЫ** *и. к.* **танкист**. *Аннан очучылар, танкчылар, кавалериячеләр, пехотачылар, рәткә тезелеп, мәйдан уртасына үтә башладылар.* Татарстан яшьләре

**ТА́НСЫ** *и. нем. к.* **танец**. *Бер тапкыр әллә кайсы гына бәйрәмдә, театрда, Сәрвәр ханым мине тансы бүлмәсенә алып китте.* Р.Батулла

**ТАНСЫК** *с.* **1.** Теләп, сагынып, көтеп алына торган, сирәк була торган. *Бу тансык күчтәнәчләрне малайлар күкәйгә алмаштырып алалар.* М.Галәү. *Шул ук вакытта бу шундый саф һәм нәзакәтле, шундый тансык һәм тирән бер тойгы иде ки, ул аны хәтта Нәфисәнең үзенә дә сиздермәскә тырыша.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ. тарт. форм.* 1) Сирәк кенә әзерләнә торган аш-су. *Тансыкка тары боткасы.* Әйтем. *Мәхрусә әбинең тансыкка дип кибеттән алып кайткан тәм-томнарына сакланып кына үрелгән иделәр, бара-тора, итагать онытылып, бер чәшке янына икенчесен өстәделәр.* Ф.Яхин

2) Нәрсәнең дә булса яңа, кызык, көтелгән чагы. – *Нәсимә әллә кияүгә*

*чыктымы? – Тансыгы узып бетте инде.* Х.Госман

**3.** *хәб. сүз. функ.* Теләп, көтеп алынган, сагынылган. *Кояш, чык, чык, чык! Синең җылың бик тансык.* Такмак

◊ **Тансык өчен** Бик теләгән, кирәксенгән вакытта. *Ә мин – кыргый җимеш, ни хәл итмәк кирәк. Җимеш тансык өчен генә, имеш. Мин дә синең килүеңне көтәм: кагыл, җитеш!..* Р.Гаташ

**ТАНСЫККА** *рәв.* Бик сирәк, озак көтеп кенә. *Әмма шул матур тешләрнең җемелдәп яктырып китүен, әти кешенең рәхәтләнеп көлүен бәйрәм кебек әллә нидә бер генә, бик тансыкка гына күрә идек.* Г.Бәширов

**ТАНСЫКЛАНУ** *ф.* Тансык нәрсәгә әйләнү, көтелү, сагынылу. *Берничә көн рәттән су өстендә килгәннән соң, коры җир ничектер тансыкланган икән.* С.Сабиров. *Шул тынычлану белән бергә икенче хис баш калкыта башлады: Казанның кысан квартирасы, шунда калган ике юеш борын тансыкланды...* Х.Ширмән

**Тансыклана бару** Торган саен күбрәк тансыклану. *Тантанага җыелган халыкның һәр сүзне алкышлап каршы алуы, журнал мөхәррирләренә олылап кул чабулар, котлау һәм тәбрикләүләр – болар барысы да чын күңелдән, соңгы вакытларда тансыклана барган, бик аз тәтегән хөрмәтләрдән иделәр.* Ф.Яхин

**Тансыклана төшү** Бераз тансыклану

**Тансыкланып китү** Кинәт тансыклану. *Соңгы вакытта йокы да тансыкланып китте әле*

**Тансыкланып тору** Күпмедер вакытка, вакытлыча тансыклану; әле, хәзер тансыклану. *Бер карасаң, хуҗабикә булган һәр өйдә бу ашлар тансыкланып тормыйдыр.* Өмет

**ТАНСЫКЛА́У** *ф.* 1) Нинди дә булса бер ризыкны ашыйсы, татыйсы килә башлау. *Шулай да, яз көнендә ит-аш мәсьәләсе уңайсыз торганлыктан, башта балыкны бер-ике көн тансыклап ашады.* Ш.Камал. *Кайчагында Фәнирә эшеннән коры-сары алып кайта, ләкин Ирекнең аның белән генә тамагы туймый, җылы аш та тансыклый.* Р.Кәрами

2) Билгеле бер затны яки нәрсәне дә булса күрәсе, ишетәсе килү, сагынып көтү. *Каян килде аңа көтмәгәндә бу хатынны тансыклау?* М.Хәбибуллин. *Күңеле тансыклаган тынычлыкны ул шунда гына таба алыр кебек иде.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Кызыксыну; кирәксенү. *Әнкәй белән без шул «ерак җирнең» хәлләрен бик тансыклап тыңлап утыра идек.* Ш.Камал. *Үз улы булмагач, ир бала тансыклый Котлыбай!* Р.Батулла

**Тансыклап бетү** Бик нык тансыклау

**Тансыклап китү** Бераз тансыклау. *Салкыннан битләре алсуланган бу сөйкемле һәм сипкелле егеткә ияреп, редакциягә барыбыз да тансыклап киткән балачак сафлыгы да килеп керде.* Өмет

**Тансыклап кую** Берара тансыклау

**Тансыклап тору** Әледән-әле, берөзлексез тансыклау; әле, хәзер тансыклау. *– Әмма укучылар сезне бик үк тансыклап тормас иде, – диде Җәмил.* Т.Әйди. *Чынлап та, ничек ирне синнән бизмәслек, сине тансыклап кына торырлык итәргә?* Х.Камалов

**Тансыклый башлау** Тансыклау сизү. *Әллә арыганлыктан, әллә башыннан кичкән авыр фаҗига тәэсиреннән, ул соңгы вакытларда ничектер басыла төште, артык ватылмыйча, тынычрак җан белән эшләүне тансыклый башлады.* Ә.Еники

**Тансыклый төшү** Бераз тансыклау. *Җаның сүрелә төшсен, татлыны тансыклый төш.* М.Хәбибуллин

**ТАНСЫКЛЫ** *с. ялг. к.* **тансык** (*1 мәгъ.*). *Мин еш кына киштәмнән аның шигырь бәйләмнәрен кулга алам һәм тансыклы бер хис белән --- Нури абыем белән булган хәлләрне искә төшерәм.* М.Хәбибуллин. *Моңа караганда да мулрак итеп, кара карлыган да, хәтта үтә тансыклы ният белән каен җиләгә дә җитәрлектән уздырып хәстәрләнгән.* Ә.Гаффар

**ТАНТАНА** *и. кыт.* 1) Күмәк халык катнашында мөһим вакыйга уңае белән рәсми рәвештә билгеләнә торган чара. *Сабырсызланып, өметләнеп, соңгы ышанычларны бәйләп дүрт күз белән көткән бөек бәйрәм – Октябрьнең егерме еллык тантанасы үтте дә китте.* И.Салахов. *Ул арада аллеяга туй тантанасы килеп керде.* Ф.Җамалетдинова

2) Өстен булу, бик югары дәрәҗәгә ирешү күренеше. *Гарәпләрдә һәртөрле фәннәрнең (бигрәк тә математиканың, астрономиянең, химиянең, медицинаның, диңгездә йөзүчелекнең һ.б.) һәм философиянең кинәт үсеп китүе, Европа өчен дә остазга әйләнүе алар арасында нәкъ менә ислам диненең тантанасына бәйле.* А.Тимергалин

3) *күч.* Бик матур, шатлыклы күренеш, хозурлык. *Күктә тантана: кояш инде шактый күтәрелергә өлгергән ---.* Н.Гамбәр

4) Горурлык һәм шатлык, канәгатьләнү хисе. *Күңелдә киңлек тантанасы булганда, урынның тар булуы берни түгел икән ул.* Ә.Фәйзи. *Тантана, чиксез канәгатьләнү кичерде ул.* З.Мурсиев

**ТАНТАНА́ ИТҮ** *ф.* 1) Уңышны, җиңүне, шатлыкны зурлап, киң колач белән билгеләп үтү. *Фәнәви --- җиңүдән тантана иткән күзләрен йөретеп, табында утырганнарны барлап чыга ---.* З.Зәйнуллин. *Ихтыярның сөмсере коелып төшкән булса, Нурислам, киресенчә, тантана итә иде.* Р.Вәлиев

2) Хөкем сөрү, өстенлек итү. *Көнозын, бөтен җиһанга тантана итеп, алтын кояш ялтырап тора.* Г.Әпсәләмов. *Гелән ел фасылыннан кыш, яз, көз айлары төшеп калсын иде дә, җир йөзендә фәкать җәй генә тантана итсен иде...* Ф.Хуҗин

**ТАНТАНА́ КЫЛУ** *ф. к.* **тантана итү**. *Сөякәев, әллә кайгырып, әллә тантана кылып, монитор экранындагы хәлләрне төп-төз басып күзәтте һәм битараф кына нәтиҗә ясады ---.* Ф.Баттал

**ТАНТАНАЛЫ** *с.* **1.** 1) Тантана (*1 мәгъ.*) төсмере булган; тантана шартларында үтә, башкарыла торган. *Соңыннан шушы уңайдан оештырылган тантаналы төшке ашка дәшәләр.* Р.Миңнуллин. *Тантаналы ант бир!* М.Кәбиров

2) Горурлык хисе уята торган. *Ә нечкә күңелле Зарифулла өчен елга бер килә торган Җиңү бәйрәменнән дә зур, тантаналы бәйрәм юк!* М.Садыйков

3) Горур, масаюлы, җиңүле; эре. *Чыннан да, Кадыйр крәстиәннәрнең зарларын түрәләргә хас тантаналы эре кыяфәт белән тыңлады.* М.Галәү.

*Тантаналы кыяфәт мизгел эчендә мыскыллы төс ала ---.* Ф.Абдуллин

4) Кемне яки нәрсәне дә булса хөрмәтләүгә, тәбрикләүгә багышланган. *Зур аудиторияләрнең берсендә химия факультетын бетергән студентларны чыгару уңае белән булган тантаналы җыелыш.* М.Галәү

5) Кадерле, өстенлекләре бик сизелеп торган. *Син монда кунак кебек тантаналы бер шартларда яшәрсең...* Р.Батулла

6) Мәһабәт, галибанә. *Идел мәһабәт, тантаналы бер тынлыкта һаман ага, һаман ага.* Г.Бәширов

**2.** *рәв. мәгъ.* Горур, җитди һәм купшы рәвештә. *Тик бүрәнә өстенә баскан Гыйльми генә, ике кулын алъяпкыч күкрәкчәсенә тыккан килеш, тантаналы көлемсерәп, тын гына карап тора иде.* А.Шамов. *Кордаш, бүген синең тавыш ничектер тантаналы яңгырый.* А.Әхмәт

**ТАНТАНАЛЫЛЫК** *и.* Тантана төсмере булу; бөеклек. *[Туй күлмәгенең] Тантаналылыгын киметү, бераз гадиләштерү өчен, Зәйтүнә аның түшенә һәм җиңенә кызыллы-зәңгәрле чигү салган иде.* М.Маликова. *--- орнаментларның да, архитектур формаларның да композицион чишелеше динамикалы төс ала, декоративлык, тантаналылык арта.* Ф.Вәлиев

**ТАНТАНАСЫЗ** *рәв.* **1.** Тантана ясамыйча, гади генә. *Ә туган көн минә шау-шуларсыз, тантанасыз гына үтте китте.* Мәдәни җомга. *[Рядовой Концов] Кичен шау-шусыз, бернинди тантанасыз Туган илгә әйләнеп кайта.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Шактый күңелсез яисә бик гадәти булган. *Тантанасыз җыелыш*

**ТАНУ** I *ф.* (таны, таный, таныр, таныячак) 1) Электән күргән-белгән кемне яки нәрсәне дә булса, яңадан очрашкач, шул үзе икәнен аңлау, белү. *Аксыл чәчле чибәр генә бер кыз, әсирләр төркеменә якын ук килеп, кемнедер танырга теләгәндәй, һәр кешегә текәлеп карап, тирәбездә озак кына әйләнгәләп йөрде.* Ф.Хуҗин. *– Бәй, бу синме әллә, килендәш, танымый да торам! – диде гаҗәпләнеп Илүзә.* З.Мурсиев

2) Кемне яки нәрсәне дә булса күреп белү, элек таныш булган билгеләреннән белеп алу. *Ни күзе белән күрсен, рәсемнең астында «Габделкаюм Насыйри» дигән язу тора. Хәзрәт сурәтне дә таныды ---.* Ф.Әмирхан

3) Үзенчәлекле билгеләреннән кешенең кемлеген, предметның нинди төрдән булуын яки аның иясен билгеләү. *Нәфисә хатның кемнән булуын адресыннан ук таныды да, алырга да, алмаска да белмичә, беравык икеләнеп торды.* Г.Бәширов. *Атлавыңнан түгел, Җырлавыңнан таныйм. Якты сагыш тулы Җырларыңнан таныйм.* Ф.Зыятдинова

4) Хәрефләрне, шартлы билгеләрне белү, язылганны укый алу. *Бу вакытта Җиһаншага унике яшь тулып, Фатыйма абыстайга сабакка йөреп, иҗек танып, сүрәгә төшеп, «Бәдәвам», «Кисекбаш» китапларын да җырлый башлаган иде.* З.Һади. *Бала тирә-юнь белән кызыксына башлаган, инде хәреф танып маташа...* А.Тимергалин

5) Берәр нәрсәнең тышкы билгеләреннән аның асылын, төп сыйфатын, үзлеген билгеләү. *Моның өчен иң элек малларны аера, таный белергә кирәк, әйе, дөрес карау шуннан башлана.* Ә.Еники

6) Кешенең характерын, холкын, кешелек сыйфатын күрә, аера белү. *Молодец, кешене таный беләсең икән!* В.Нуруллин. *Дөнья гаме белән күңел гамен аерырга өйрәндем. Кешеләрне танырга өйрәндем...* Г.Гыйльманов

7) Дөньяны, яшәеш-тормыш, чынбарлык күренешләрен аңлый белү. *Дөньяны таныган – карт булыр, юлны таныган – ат булыр.* Мәкаль

8) Килешү, ризалашу, кабул итү. *Укытучы башка берни әйтми, ләкин малайлар төшенәләр, гаепләрен танышлар, һәм Нургали абыйның икенче килүенә кимчелек инде төзәтелгән була.* А.Тимергалин. *Ләкин мин сине аңлыйм, бүгенге көндә синең үз хаталарыңны танып тәүбә итүең, дөрес юлга басуың мөһим.* З.Мурсиев

9) Рәсми, тулы хокуклы дип табу. *Петроград гарнизонындагы полкларның вәкилләр киңәшмәсе Вакытлы хөкүмәтне танымаска, бары Петроград Советын гына танырга, [аның] приказына буйсынырга карар чыгарган.* Ш.Камал

10) Исәпләү, санау, билгеле фикердә, мөнәсәбәттә булу. *Миллионнарча минем дусларым дан эше дип таный хезмәтне.* М.Җәлил. *Законсыз дип тану*

11) Санлау, хөрмәт итү; санашу, исәпләшү. *Сарай даирәсе дә бу дәрәҗәне таный иде.* М.Әмирханов. *Чөнки дәүләт бүләге алу бәләкәй нәрсә түгел, бу сине --- кешеләр дә таныды дигән сүз.* М.Кәбиров

12) Кемне дә булса берәр сыйфатларга ия дип табу. *Купедагы малай халкы беренче минуттан ук Азатны бәхәссез лидер итеп таныганга, арада бернинди каршылык килеп чыкмый.* А.Тимергалин. *Гомере буе һәммә кешедән өстен чыгарга өметләнгән, үзен мескен итеп танырга теләмәгән бәндәне Галимулла ишеләрнең сурәте дә чыгырдан чыгара, саруын кайната шул.* Ф.Яхин

**Таный башлау** Бераз таныган кебек булу. *– Кем син, әрәмтамак, әллә инде бәкләрегезне танымый да башладыгызмы? – дип, Чура сакчыбашның якасыннан эләктереп алды.* М.Әмирханов. *Әллә безнең Гамир йолдызларны таный башлаганмы?* Ф.Яхин

**Таный төшү** Бераз таныган кебек булу. *Фамилияләрен атауга, әтиәниләренә ошатып таный төштем авылдашларны.* Якты юл

**Танып алу** Тиз арада яхшы ук тану. *[Җиһан әби] Танып алуга ук киң итеп елмаеп җибәрде, үз итеп аркамнан сөйде, аннары түргә дәште, артсыз урындыкның читенә генә утырып дога кылды...* Г.Гыйльманов. *Арадан берсен танып алам.* Ф.Яхин

**Танып бетерү** Тулысынча, кем яки нәрсәне төгәл күрсәтерлек дәрәҗәдә тану. *Авылның кайбер өлкәнрәк агайлары мине танып та бетермиләр, уртанчы абыйның исемен әйтеп: «Гариф», – дип исәнләшәләр.* Ф.Хуҗин. *Аны танып бетерә алмадылар, әмма, күренеп тора: ак сакаллы, ак чәчле бу карт аларны таный, белә...* Г.Гыйльманов

**Танып җиткерү** *к.* **танып бетерү**. *Яңгыравыклы малайлар тавышын*

*аерым-аерым танып җиткереп булмады ---*. А.Тимергалин

**Танып җитү** Тәмам тану. *Берничә минутлар үтеп, мәет әүвәлге, терелү төчкерүен төчкергән вакытта, Фәтхулла хәзрәт тә инде аны танып җиткән иде*. Ф.Әмирхан

**Танып тору** Һәрдаим тану. *Татар, башкорт җыелган урыннарның барысында да танып торалар, тегеяки бу әсәрем турында сүз кузгаталар, әле нәрсәләр язуым белән кызыксыналар.* М.Кәбиров

**ТАНУ** II *ф.* (тан, тана, танар, таначак) Нәрсәдәндер баш тарту, нәрсәнедер кире кагу, инкяр итү. *Бер кызардым, бер бүзәрдем... Ни таныйм?.. таналмадым!* Дәрдемәнд

**ТАНУЛЫ** *с.* Берәр билгесенә карап танып була торган. *Лачын кош очуыннан танулы.* Мәкаль

**ТА́НЦЫ** *и. нем. сөйл.* 1) *к.* **танец**. --- *Нәкъ сәгать сигездә клубта кино башлана, ә аннары танцы була.* Г.Әпсәләмов. *Һәм яшьләр бераздан, авыл уеннарын тәмамлап, танцыга күчтеләр.* Ф.Яруллин

2) Классик бию көе. *Ул шул гармунында такмаклардан, танцылардан алып озын арияләргә кадәр – һәммәсен уйный.* Г.Тукай

**ТАНЫК** *и.* 1) Берәр эш-хәлне, җинаятьне күреп, белеп, шуны раслаучы кеше, шаһит. *Габдуллиннарга кич белән Байчурин ике танык һәм берничә милиционер ияртеп килеп кергәч, хуҗа каушый калды.* Т.Әйди. *Күктә – кояш танык, җирдә – Итил танык: бабам, атам туган чакта Итилнең үрге агымы – Ука суынача, түбән агымы – Кызлар тавынача, Чулманның Ала Бука катауга тикле барлык җир-сулары Болгарныкы булган.* Н.Фәттах

2) *диал. к.* **таныклык** (*4 мәгъ.*). *Инде балам туды. Тууы турында танык алдым.* Х.Сарьян

**ТАНЫКЛАМА** *и.* 1) Таныкның булган вакыйга-хәлләр турында хикәяләве. *Таныкламага таянып җинаятьчене ачыклау*

2) Белешмә, таныклык кәгазе; таныкнамә, шәһадәтнамә. *Өч-дүрт мәкаләм басылып чыккач, мине «На страже Родины» редакциясенә хәрби корреспондентлар киңәшмәсенә чакырдылар һәм штаттан тыш хәрби хәбәрче таныкламасы биреп җибәрделәр.* В.Нуруллин. *Гали машинадан чыгачыгышка ук хезмәткәргә берьюлы ике таныклама суза ---*. Ф.Баттал

**ТАНЫКЛА́У** *ф.* 1) Күргән вакыйгаларны танык итеп хикәяләү. *Без ошбу намәгә кул куючылар --- олуг падишаһыбызның мәрхәмәтле вә тугрылыклы түрәләренә шуны таныклыйбыз: Мөхәммәтсалих улы Таҗетдин Миңлебаев – безгә үзенең инсафсызлыгы вә әдәпсез гадәтләре белән күптән мәгълүм адәмдер.* М.Галәү

2) Нәрсәнең дә булса дөреслеген раслау. *Иң ахырда Фәйзулла куштан: «Мин, силски староста Фәйзулла Җамалетдин углы, гуаһлап кулым куйдым һәм таныклап кәҗүнни мөһер бастым», – дип язды.* М.Галәү

**Таныклап тору** Әле, хәзерге вакытта таныклау

**ТАНЫКЛЫ** *с.*1) Танылган, мәшһүр, билгеле. *Анда бөтен дөньяга таныклы Азатлык сыны тора.* Казан утлары. *Студентлар узган йөзьеллыкта яшәгән таныклы балериналар: Матильда Кшесинская, Агриппина Ваганова, Анна Павлова һәм Галина Улановалар тормышы белән якыннан таныштылар.* Бөгелмә авазы

2) *диал.* Танытып торган берәр тамгасы булган. *Бу сыерның таныклы билгесе бар: бер мөгезе сынган*

**ТАНЫКЛЫК** *и.* 1) Шаһитлык; танык, шаһит, гуаһ булу. *Бала таныклыкка ярамый, аның сүзен дәлил итмә.* Н.Исәнбәт

2) Берәр факт, вакыйга-хәл турында шунда булган кешенең хәбәр итүе, мәгълүмат бирүе. *Синең хәлне ул бишектә килеш күрде, Синең өчен ул таныклык бирә белде, – Ни сәбәптән сиңа лаек түгел имди?!* Кол Гали. – *Алланың берлегенә вә аның пәйгамбәре Мөхәммәд булуына таныклык китерәм! – дип белдерде [ул].* Ф.Яхин

3) Судта шаһит күрсәтүләре, таныклама. *Шуннан соң судьялар киңәшкә кереп киттеләр дә, бераздан чыгып, Хафизның акланганлыгын, Кәрим иярченнәренең ялган таныклык биргәнлекләре өчен судка биреләчәкләрен әйтеп, ябарга алып киттеләр.* Г.Камал

4) Юридик мәгънәгә ия булган берәр фактны раслый, яки шәхеснең нәрсәгә дә булса хокукын күрсәтә торган рәсми документ, шәһадәтнамә. *Бөтенесе: килен дә, оныклар да паспорт, туу турындагы таныклык юнәтеп ерак юлга чыктылар, карчык исә үз нигезендә калды.* М.Мәһдиев. *Курсантларга сержант дәрәҗәсе бирелеп, укчы-радист таныклыклары өләшенде.* Ф.Хуҗин

5) Нәрсә турында булса да анык мәгълүмат; раслама. *Мәкаль нине дә булса раслый, таныклык бирә, ышандыра яки кире кага.* Н.Исәнбәт

**ТАНЫКНАМӘ** *и. к.* **таныклык** (*4–5 мәгъ.*). *Ул эчке кесәсеннән таныкнамәсен эзләргә тотынды.* А.Шамов. *– Хуҗиәхмәт минем белән төркемләүтарату пунктына китәр, туу таныкнамәләрен хәзер үк кулыма тапшырыгыз, – диде [ул].* Р.Рахман

**ТАНЫКСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Таныктан башка; шаһитсыз. *Таныксыз гына башкарып чыгу*

2) Танырлык түгел, танылмаслык хәлдә

**2.** *с. мәгъ.* 1) Таныгы, шаһиты булмаган. *Таныксыз җинаять*

2) Танырлык булмаган, танымаслык. *Таныксыз язу*

3) Билгесез; анык билгеле булмаган, исбатланмаган. *Атасын сорасаң – таныксыз, анасын сорасаң – белексез.* Әйтем

4) Мәгънәсе ачык булмаган. *Таныксыз сүз иярсез ат кебек.* Мәкаль

**ТАНЫЛГАН** *с.* 1) Күпләргә билгеле, таныш булган. *Танылган факт*

2) Күренекле, мәшһүр; данлыклы; атаклы. *Бөтен кеше дә танылган җырчы хатыны булып бетә алмый.* Р.Сәгъди

**ТАНЫЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тану** I. *Дөньяның кыйммәтләре чагыштыруда танила.* Л.Ибраһим-Вәлиди

2) Кемне яки нәрсәне дә булса аерым билгеләреннән танырга мөмкин булу. *Алдагыларның Әсма белән Госман икәнлеге сыннарыннан вә ишетелеп киткән тавышларыннан танила иде.* Ф.Әмирхан

3) Шартлы билгеләрне яхшы, ачык аңлардлык булу, уку мөмкин булу. *Кәрим: «Я, ярар инде шунда, язуы танылса җитәр».* Г.Камал. *«Антыма», «ирәнемә», «бөлген» сүзләре таныла монда.* Ф.Мөслимова

4) Берәр сыйфатка ия дип билгеләнү, исәпләнү. *Болгар нәрсәләре чит ил базарларында атаклы, һәркемгә ошаулы нәрсәләр булып танылалар.* Ш.Әхмәдиев

5) Табылу, билгеле үзенчәлеккә ия булуы раслану. *Союзның губерна съезды тарафыннан Хәйринең әтисе Мохтар абзый эш батыры дип танылды һәм күп кенә бүләкләр белән тәбрикләнде.* Ш.Камал

6) Дан казану, билгеле, мәшһүр булып китү. *Тарихта ул Бөек Болгар дип таныла.* Р.Батулла

**Танıла бару** Торган саен күбрәк танылу. *Рим империясе җимерелүгә йөз тота, ә менә Византия империя буларак дөнья халыкларына таныла бара.* М.Хәбибуллин

**Таныла башлау** Әле генә танылу алу. *Училищедан киткәндә, районда гына түгел, республикада да таныла башлаган идем инде.* М.Кәбиров

**Таныла тору** Һәрберсе даими, бер-бер артлы танылу. *Ни хикмәт, аларның яңалары туа, таныла тора.* Ватаным Татарстан

**Таныла төшү** Тагын бераз танылу

**Танылып алу** Тиз арада танылу. *Җитмешенче еллар башында ул Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау өлкәсендә танылып ала ---.* Л.Хәмидуллин

**Танылып бару** *к.* **таныла башлау**. *Шигырьләре белән танылып баручы егетне әдәбият-сәнгать бүлегенә эшкә алдылар.* Г.Гомәр

**Танылып бетү** Нык танылу, һәркемгә танылу. *Балык Бистәсеннән Казан каласына килеп эләккән Рөстәм, үзен Шәкерт дип атап, бөтен Рәсәйгә танылып бетте.* Шәһри Казан

**Танылып җитү** *к.* **танылып бетү**. *Аларга инде бу кара чәчле егет үзләренең сөекле яшь язучылары булып яхшы ук танылып җиткән иде.* М.Җәлил

**Танылып йөрү** Әйтелгән, сөйләгән вакытта танылу. *Безнең арада моңарчыга кадәр каты бәгырьле усал малай булып танылып йөри иде [ул].* Ә.Еники

**Танылып килү** Әле яңа таныла башлау. *Ә Маратның инде тирә-юньдә гармунчы, спортчы буларак танылып килгән чагы.* Д.Гыйсметдин. *Ул Уралда, Россия төбәкләрендә, чит илләрдә төрле күргәзмәләрдә катнашып танылып килә.* Казан утлары

**Танылып китү** Кисәк танылу. *Ләкин якынрак танышкач, мин аның кайчандыр хуҗалык эшләрендә эшләп йөргәнен, тик соңгы вакытларда гына курайчы булып танылып киткәнен белдем.* Ә.Еники. *Унөч яшендә [ул] Троицк шәһәрендәге туганнарына китеп, тегүчелек эшенә өйрәнә һәм танылып китә.* Т.Нәҗмиев

**Танылып кую** Кинәт танылу; азга гына танылу. *Шулай көтмәгәндә генә Франциянең киң җәмәгатьчелегенә танылып куйган яшь маэстро ---.* А.Хәсәнов

**Танылып тору** Даими танылу; әле, хәзер танылу. *Ул фотолардагы ир кешенең яшьлегенә-өлкәнлегенә карамыйча, һаман да шушы агай икәнлеге танылып тора.* К.Кәримов. *Мәктәп автобуслары ерактан танылып тора.* Кызыл таң

**ТАНЫЛУ** II *и.* Популярлык, танылганлык. *Танылу аңа тиз килде, бәлки шуның өчен дә ул йолдызлык чиренә тиз биреште.* Р.Ахунова

**ТАНЫ́П БЕЛҮ** *и. филос.* Әйләнә-тирәне өйрәнеп, тикшереп белем тупларга юнәлтелгән эшчәнлек. *Хикмәт шунда ки, безнең акылларыбыз танып белү көченә ия.* Ф.Яхин. *Алар гомумкешелекнең дөньяны танып белү кануннары турында озак сөйләштеләр.* А.Нәҗми

**ТАНЫТКЫЧ** *с.* **1.** Танылу һәм белү өчен махсус билгеләнгән. *Таныткыч билгеләр*

**2.** *и. мәгъ. махс.* Берәр нәрсәне тану, охшаш төрләрдән аеру өчен, аның төп билгеләре күрсәтелгән кулланма (китап, таблица, схема); *русчасы:* **определитель**

**ТАНЫТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тану**. *Яшерен дусның кем булуын, ни өчен үзен танытмаска тырышып йөрүен беләсе килде.* Г.Гобәй

2) Кемнең дә булса исемен һ.б. әйтеп таныштыру. *Ул яңа килгән егетләрнең сумкаларын алып, сәкегә үз урыны янына урынлаштыргач, аларны мондагы иптәшләренә дә таныткан булды ---.* Ш.Камал

3) Өйрәтү, белем бирү. *Бу каза Шәмси мулланы кайгыга төшерсә дә, аны авыл малайларына әлифба танытудан, ә өлкән шәкертләргә дин сабагы укытудан коткарды.* М.Галәү

4) Нәрсәне дә булса аңлатып, күрсәтеп тору. *Үсемлеккә бай төбәктә аларның ак кар белән капланган чипчиста йөзләре биредә су булуын әллә кайдан танытып, гаҗәп матур булып күренә иде.* З.Мурсиев

5) Асылын, үзенчәлекле сыйфатын белдерү, үз-үзен күрсәтү. *Үзен бау ишүче дип таныткан иде [танышы].* М.Галәү. *Бу мөртәт гомере буе астан кисеп өстән ямады, халыкның күзенә төтен җибәрде, үзен кочак-кочак буш вәгъдәләр бирүче авантюрист итеп танытты.* Ф.Садриев

6) *сөйл.* Үзен кабул иттерү, үзен билгеле бер сыйфатта танытырга мәҗбүр итү. *Туры килерсең әле, танытырмын әле мин сиңа кем икәнлегемне.* А.Шамов. – *Танытам мин аларга, – дип шәпләнде Шәүкәт, – минем алда биеп кенә торачаклар, күр дә тор.* К.Кара

**Таныта башлау** Танытырга тотыну. *Шуңа карамастан кеше рәхәтләнеп үзен булдыклы, намуслы, мөрәүвәтле герой рәвешендә таныта башлый.* Т.Әйди

**Таныта төшү** Тагын да бераз таныту

**Танытып бару** Акрынлап, даими рәвештә таныту

**Танытып килү** Билгеле бер вакытка кадәр даими, эзлекле рәвештә таныту. *Алар төрле фокуслар ярдәмендә үзләрен сихри көчләр хуҗасы итеп танытып килгәннәр.* Р.Гарифуллин. *Олы Кайбыч мәктәбенең хоккей командасы үзен республика ярышларында 2008 елдан бирле танытып килә.* Кайбыч таңнары

**Танытып тору** Даими яки әледән-әле таныту; әле, хәзер таныту. *Чөнки аларның һәммәсе диярлек, төзелеш кәгазьләренә кул куйдырырга дип, Кадрия каршына килеп, үзен танытып тора.* В.Имамов. *Татар осталарының*

*данын халыкара күргәзмәләрдә ул еш танытып тора.* Казан утлары

**ТАНЫШ** *с.* **1.** 1) Кем икәнлеге анык билгеле булган, күргән-белгән, ишеткән. *...Баштан үткән еллар, таныш кешеләр, аларның фигуралары, экранда алмашынып торган күренешләр кебек, бертуктамый алмашынып торалар.* А.Алиш. *Илчелекнең сәркатибе сыйфатында эш иткән Ибне Фазлан – безгә байтактан таныш шәхес.* А.Тимергалин

2) Электән белгән, мәгълүм булган; күнегелгән. *Бик сагындым таныш кырларымны, Урманымны, күпер башымны.* М.Җәлил. *Чү, кайдандыр Газинурга бик яхшы таныш озын-озын зырылдау бер нечкәргәндәй була, бер тагын да калыная төшә.* Г.Әпсәләмов. *Әйе, Фазылга таныш, бик таныш изге җыр бу!* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Күргән-белгән, кем икәнлеге билгеле булган кеше. *Көянтәчиләкләрне элеп, суга барырга чыгасың, юлда танышлар очрый.* А.Алиш. *Югыйсә минем бер танышым әйтмешли, татар күрмичә ышанмый.* Ф.Яхин

**3.** *хәб. сүз* 1) Күптән билгеле, танылган хәлдә. *Таныш миңа сугыш газаплары.* З.Мансур. *Адресны язган кул һич таныш түгел, һәм конверт бик юка иде.* Ә.Еники

2) Хәбәрдар. *Чәчү, җир сөрү эшләре белән дә мин бик яхшы таныш.* Ш.Камал

**ТАНЫ́Ш-БЕЛЕШ** *җый. и.* Таныш булган, белгән, күз күргән кешеләр. *Йөри торгач, арадан берәр танышбелеш чыгуы да бар.* Ф.Хөсни. *Ләкин ярдәм күрсәтерлек таныш-белеш булмау, акчасызлык аркасында, берсенә дә урнаша алмый.* М.Галәү

**ТАНЫШЛА́РЧА** *рәв.* Үзара таныш кешеләргә хас булганча. *Өченче көнне Александринкада икесе дә иске танышларча күрештеләр.* Г.Исхакый. *Шәһәр вокзалында иске танышларча саубуллашып аерылыштылар.* Г.Минский

**ТАНЫШЛЫ** *с.* Дуслары, танышлары, эшнәләре булган. *Танышлы егетебез бу юлы да безгә булышты*

**ТАНЫШЛЫК** *и.* 1) Үзара таныш булу. *Ялгышасың, тәкъсир, андый адәмнәр белән танышлыгым юк минем.* М.Галәү. *Шул аерылудан безнең танышлык онытылган иде.* М.Әмир

2) Таныш-белешләр күп булу. *Кыскасы, танышлык оҗмахка да кертә, гүрдән дә чыгара.* Ф.Садриев

3) Нәрсәнедер күргән, белгән, анда күпмедер яшәгән, торган булу. *Иптәшләр исә күлнең, тирә-якның матурлыгыннан, танышлыгыннан бигрәк җил булмауга куаныштылар; чөнки җил-давыл булса, күл тулкынлана да, каптыруның кызыгы калмый, балыклар да юньләп эләкми башлыйлар.* Г.Ибраһимов

4) Нәрсәне дә булса җитәрлек дәрәҗәдә белү. *Кошлар белән танышлык чамалы булганлыктан, без бу кошчыкларның нинди заттан икәнлекләрен белмәдек.* Ә.Моталлапов. *Фоат Миңлеәхмәт улы һәм Шәмсия Гатуф кызының иҗатлары белән күптән танышлыгым бар иде.* Т.Нәҗмиев

**ТАНЫШЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Таныш булып, аралашып, танышлыкны саклап тору. *Гәрәй морзаның шундый кодрәткә ия булуына, шундый асыл затлар белән танышлык итүенә хәйран калып утырган беркатлы Әкрәм карый сөенеп бетә алмады.* М.Галәү

**ТАНЫ́Ш-ТОНЫШ** *җый. и.* Һәртөрле таныш кешеләр, таныш-белеш. *Бозлы окоп, авыр сугышлар, Үлеп калган таныш-тонышлар.* Г.Афзал

**ТАНЫШТЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсә турында мәгълүмат бирү, таныту, хәбәрдар итү. *– Безнең мәчеттә сезгә бик гаҗәп тоелыр, муллаларның вәгазе дә, клубтагы тәбрик мәҗлесе дә, театрлар, концертлар да... әлхасил, һәммә нәрсә дә сезгә бик гаҗәп тоелыр, – дип, иртәгә үзенең танытырачак җирләренә кагылышлы бераз сөйләде [ул].* Ф.Әмирхан. *Сафагәрәй Казандагы теләктәшеннән хәбәр алган иде, бине шуның белән таныштырырга ашыкты.* М.Әмирханов

2) Кемне дә булса икенче берәү белән таныш итү, исемнәрен әйтеп берберсенә күрсәтү. *– Рәхмәт, – диде теге һәм үзен Аланлы МТСының директоры Зәйнуллин дип таныштырды.* Г.Минский. *Патша исә һәрбер очраган кешене: «Менә минем булачак хатыным, җир йөзендәге иң гүзәл зат шушы була инде, таныш булыгыз», – дип таныштырган.* Г.Гыйльманов

**Таныштыра бару** Эзлекле рәвештә таныштыру. *Наилә ханым юлда шәһәр тарихын татар халкы белән бәйләп, таныштыра бара.* Н.Гариф. *Муса аны әдәбият-сәнгатькә кагылышлы һәр эш белән таныштыра бара иде.* Казан утлары

**Таныштыра башлау** Таныштырырга тотыну. *Күрешеп, исәнләшеп беткәч, егетләр, берсен берсе уздырырга тырышып, Сафаны авыл яңалыклары белән таныштыра башладылар ---.* М.Галәү. *Икәүдән-икәү генә калгач, Бариәхмәт кунакны үз эшенең нечкәлекләре, үзенчәлекле яклары белән таныштыра башлады.* М.Хәсәнов

**Таныштырып алу** Тиз генә таныштыру. *Ул кемгә сүз кушса, шуның белән таныштырып та ала.* К.Тимбикова. *– Рәхим итегез, түргә узыгыз, аяк киемегезне салмагыз, үзем дә туфлидән йөрим, – диде ул, шул арада Әмирҗан исемле икәнлеген әйтеп, үзе белән таныштырып та алды.* Ф.Садриев

**Таныштырып бару** Даими таныштыру. *Һәр яңа китап, әдәбияттагы яңалыклар белән балаларны нәкъ менә ул таныштырып барырга тиеш лә!* Г.Әдһәмова

**Таныштырып китү** Тиз генә таныштыру; җае, уңае чыгып таныштыру. *Рөхсәт итегез сезне артистларыбыз белән таныштырып китәргә!* Г.Каюмов. *Корбан белән якыннанрак таныштырып китмәссеңме?* Ф.Бәллүр

**Таныштырып кую** Тиз генә, җиңел генә таныштыру. – *Таныш бул, Хәлим, бу Флюра була, быел гына университетның филология факультетын тәмамлады, – дип, аларны бер-берсе белән таныштырып та куя [ул].* Ф.Мөслимова

**Таныштырып тору** Даими яки әледән-әле таныштыру; әле, хәзер таныштыру. *Кичкә кадәр күрше-күләннең хәл-әхвәлен белешеп, яңалыклар белән таныштырып тора.* Р.Галиуллин. *Шуңа күрә республикада, илдә барган яңалыклар белән таныштырып тору – аның бурычы.* Өмет

**Таныштырып үтү** Сүз уңаеннан, нәрсәдер барышы белән бергә таныштыру. *Мәсьәлә яхшырак аңлашылсын өчен, мин сине бер вакыйга белән таныштырып үтәм.* Г.Кутуй. *Форсаттан файдаланып, китап укучыларыбызны да таныштырып үтик әле җиңүчеләребез белән.* Т.Нәҗмиев

**Таныштырып чыгу** Һәммәсе белән дә таныштыру; тулысынча таныштыру. *Ишегалдындагы каралты-кура белән таныштырып чыккач, хуҗа кеше кунакларны өйгә керергә чакырды.* М.Галәү. *Барысы да табын тирәли утырышкач, Идекәй өлкән хатын белән һәммәсен дә таныштырып чыкты.* М.Хәбибуллин

**ТАНЫШУ** *ф.* 1) Берәр нәрсә турында мәгълүмат алу, белем туплау. *Кырмыскалар йортын кунаклар җентекләп йөреп чыктылар, аның һәр почмагы белән таныштылар.* А.Алиш. *Ә математика, механика, химия кебек фәннәрдән татарча дәреслекләр төзүчеләргә мин иске китапларда, заманында мәдрәсәләр өчен язылган дәреслекләрдә очрый торган терминнар белән --- танышырга киңәш итәр идем.* А.Тимергалин

2) Берәр рәсми кәгазьне, документны махсус рөхсәт белән карау, өйрәнү. *Соңгы елларда, авыллар тарихын язар алдыннан, байтак кына дәүләт архивларында булып, бу мәсьәләгә кагылышлы материаллар белән танышырга туры килде.* Кәеф ничек?

3) Кем белән дә булса танышлык мөнәсәбәтләренә керү. *Миңа Осланда Гариф исемле бер әфәндене күрергә һәм аның белән танышырга кирәк иде.* Ф.Әмирхан. *Гәүһәршад яшь кәләш белән мәҗлестә генә күрешеп танышырга булды.* М.Әмирханов

**Таныша бару** Әзлекле рәвештә танышу. *Мондый хәбәрләр белән таныша барган саен, әтием алдындагы счётның бер төймәсен шалт итеп тартып куя килде.* А.Хәсәнов

**Таныша башлау** Танышырга тотыну. *Ләкин гуннарның биредәге тормышлары белән таныша башлагач, алай дип язарга да, әйтергә дә кыймады Приск.* М.Хәбибуллин

**Таныша тору** Әлегә танышу. *Әйдә, ашыкмыйк әле, күңел дәфтәрләренең миндәгесе белән таныша торыйк.* Ф.Садриев. *Мин килгәнче, ул анда юлларын өйрәнә, таныша тора.* Р.Вәлиев

**Таныша төшү** Бераз гына танышу; тагын да тирәнрәк танышу. *Соңрак, бераз таныша төшкәч, үзем сорап алырмын.* Ә.Баян. *Бу мәсьәләдә минем башта ук үз фикерем бар иде, фаҗигале вакыйгалар агышы белән таныша төшкәч, ул фикер тагы да ныгыды.* Безнең гәҗит

**Танышып алу** Тиз генә танышу. *Кай ара Галя белән танышып алган.* А.Алиш. *Чыннан да, Вера бу мизгелдә өйдә юк иде, тиз арада танышып алган кызлар белән ул мәш килә.* З.Мурсиев

**Танышып бару** *к.* **таныша бару**. *Болгар укучысы чит ил әдәбиятлары казанышлары белән вакытында танышып бара аламы?* Т.Әйди. *Шул ук вакытта үзлегеннән дә күп укып, авыл хуҗалыгына кагылышы булган яңалыклар белән танышып бара [ул].* В.Нуруллин

**Танышып бетү** Барысы белән дә танышу; җитәрлек дәрәҗәдә танышу. *Инде шактый яхшы танышып беткәч, гадәти сөйләшүдән чыгып китеп, дин турында гәп кузгалып китә иде.* З.Мурсиев. *Ул шәһәргә килгән беренче көнендә үк, ишектән дә чыкмыйча, йорттагы бөтен кеше белән диярлек танышып бетә язды.* И.Нәбиуллина

**Танышып җибәрү** Тиз генә танышу. *Әйдә, танышып җибәр ---.* Н.Әхмәдиев

**Танышып җитү** *к.* **танышып бетү**. *Башкалар арасында, дачада егетләрнең күплеген, хәзер инде аларның һәммәсе белән үзенең танышып җиткәнлеген Лиза үзенә бертөрле кәефләп сөйләде.* Ф.Әмирхан

**Танышып китү** Җае чыккан арада танышу. *Кунаклар арасында шау-гөр килеп бара торгач (безме күреп алдык, алармы безне күреп алды), якында гына утырган ирле-хатынлы кешеләр белән танышып киттек.* Ф.Хөсни. *Язга таба алар танышып китәләр.* А.Тимергалин

**Танышып кую** Алдан ук танышу. *– Танышып кую яхшы булыр, – дип сүз башлады ул, өченче тапкыр танцыга чыккач.* Д.Каюмова

**Танышып тору** Даими яки әледәнәле танышу; әле, хәзер танышу. *Аларга нигә танышып торырга, алар болай да бер-берсен би-ик күптән беләләр.* Ә.Еники

**Танышып узу** Берәр эш-хәл, сүз барышы уңаеннан танышу. *Нәтиҗәсе белән без инде танышып уздык ---.* В.Имамов. *Тәнкыйтьченең сәнгатьчә гүзәллеккә (категория прекрасного) мөнәсәбәте белән танышып узу да кызыклы булыр.* Р.Мөхәммәдиев

**Танышып чыгу** Рәттән, башыннан ахырына кадәр барысы белән дә танышу. *Икенче көнне эшкә килгәч, ул, авыру янына кереп, өр-яңадан танышып чыкты.* Г.Гыйльманов. *Ләкин 35 ел әдәбият дөньясында кайнау дәверендә мин татар язучыларының күбесе белән танышып чыктым һәм дуслаштым...* Шәһри Казан

**ТАҢ** I *и.* 1) Кояш чыгар алдыннан көнчыгыш ягыннан таралган яктылык; иртәнге шәфәкъ. *Сыек кына итеп җәелгән таң яктысында томан эченнән фин солдатлары атлыйлар иде.* З.Зәйнуллин. *Инде офыкта таң беленә башлагач (бирердә таңнар бик иртә ата икән), Игорь, бөтен нәзакәтен, илтифатын туры китереп, Нурисәне бүлмәсенә озатып куйды...* Г.Галиева

2) Кояш чыгар алдыннан караңгылык таралу, яктыру вакыты, кояш чыгу мизгеле; көннең төн белән иртә арасындагы өлеше. *[Сандугач:] Чут-чут, чут-чут, Минем җырым таң турында. Җырым туа таң нурында, Чут-чут, чут-чут, трил-трил, чут-чут.* Т.Миңнуллин. *Язмыш – таң кебек: башы бар, ахыры юк...* Г.Гыйльманов

◊ **Таң аттыру** 1) Таң атканда уяу булу, таң атканны күзәтеп тору. *Ак бабай белән атлар көтәргә баралар да шунда кунып калалар иде, көтүче куышында таң аттыралар, офык артыннан кояш калыкканын күзәтәләр...* Г.Гыйльманов; 2) Таң җиткәнне көтеп алу. *Әйе, кайчагында менә шуларны уйлыйсың да үзеңнең йокыларың кача, таң аттыра алмыйча интегәсең...* А.Тимергалин. *Бүтән күрмәсәм,*

*үлермен кебек тоелды, көчкә таң аттырдым, икенче көнне очратканда, мин инде аны беркайчан беркемгә бирмәячәгемне аңладым.* З.Кадыйрова. **Таң ату** Кояш офык сызыгыннан күтәрелмәс борын, күк йөзендә яктылык барлыкка килү. --- *бервакыт лаштырлоштыр атлап килгән берәүнең нәкъ безнең машина янында туктап калуы сискәндереп җибәрде: таң ката нишләп йөри бу бәндә?* Н.Гамбәр. **Таң сарысында** *диал.* Таң атыр-атмас. *Сабый чагында изелеп, ишелеп, бишек йокысы белән йоклар урында йомык күзләр белән таң сарысында маллар куган Карлыгач боларын да аңлый.* А.Хәлим. **Таң сызылу** Офык сызыгында яктылыкның беренче билгеләре күренә башлау. *Чорма тәрәзәләрен аландырып таң сызылганда, Фәхерниса карчык ат абзарларына барып җитә.* М.Мәһдиев. *Таң сызыла башлау белән торып, атларны җиктек, әйберләрне төядек тә кайтырга чыктык.* В.Нуруллин. **Таң тишеге** *туп.* Төн белән таң арасы, иртәнең башланып җитмәгән вакыты. *Таң тишеге белән вокзалга төшеп, электричкага утырып та киттек.* Г.Гыйльманов. *Таң тишеге белән шалтырату килешеп бетмәс.* М.Кәбиров. **Таң тишегеннән** *туп.* Бик иртә, иртә таңнан ук. *Әмма таң тишегеннән бөтен авылны дер селкетеп йөрү килешмәс дип, Укмас басу капкасы төбендә тукталды ---.* В.Нуруллин. *Бүген таң тишегеннән районга чакырттылар әле.* З.Хөснияр. **Таң туса (туды исә, туган саен)** Һаман, гел, һәр көнне, Ходай бирмеш көн. *Бурычтан башым чыкмый. Шул бер борчу, таң туса... Әҗәткә сорамас идем, Китапларым сатылса.* К.Булатова. **Таң туу** Таң ата башлау. *Елмая һәр көн кояш, сызылып офыктан таң тугач... Кич көмеш ай калка офыктан, бишегенә яткач кояш...* Г.Сөнгати. *...Җил тынган, Су тынган. Таң туган. Төн узган.* И.Юзеев. **Таң яру** Офыкта сызык рәвешендә генә яктылык барлыкка килү. *Китәр вакытым минем җитә бара, Уйла-кара, җаныем, таң яра.* Жыр. **Таң ярылу** *к.* **таң яру**. *Шул вакыт дөнья йөзен каплап торган Пәрдә күтәрелде, таң ярылды. Ыргылып чыкты нурлар таң яныннан ---.* Н.Думави. *«Таң ярылу» очрагында яру сүзе белән борынгы төркидәге ярук/йарук – «яктылык» сүзе арасында параллель үткәреп була.* А.Тимергалин. *Механизатор әтиләребез көнен һәм төнен кырдан кайтмыйча җир сөрделәр, иген үстерделәр, әниләребез таң ярылганнан алып кичкә кадәр ферманың авыр хезмәтендә чиләнде.* Г.Шиһапова

**ТАҢ** II *хәб. сүз. иск.* **1.** Мөкиббән китү, соклануны белдерә. *Калган күлгә – бака хан. Бай хатынына – ялчы таң.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Сокландыргыч, гаҗәеп матур. *Таң, таң ата, чулпан калка, Чулпан таңны уята.* Җыр

◊ **Таң булу** *к.* **таң калу**. **Таң итү** *к.* **таң калу**. **Таңга калдыру** *к.* **таң калдыру**. *Адәм балалары арасында шундый да акыллылары бар ки, алар үзләренең булдыклы, әдәпле, гыйлемле булулары белән таңга калдыралар.* Ф.Яхин. **Таңга калу** *к.* **таң калу**. *Тирәннәнрәк уйлый төшсәң, таңга калырлык бит: тирән эчтәлекле, укып туймаслык китап иҗат иткән.* М.Хәсәнов. *Җыр көенә уйный дулкыннар, Таңга калып, таллар баш ия...* Р.Сәйфетдинов. **Таң калдыру** Гаҗәпләндерү; сокландыру. *Кичә генә җомга намазында барыбызны таң калдырган мулла абзый ничек инде җыен көнендә генә авырып китсен ди.* Г.Галиева. *Ул мине теге чакта ук медицина гыйлемен яхшы белүе белән таң калдырган иде.* З.Мурсиев. **Таң калу** Бик нык гаҗәпләнү, хәйран калу; соклану, мөкиббән китү. *Яшь мулланың Коръән укуын үтенгәннәр. Егет һич ялындырмыйча укыган. Мәкаме шулкадәр матур икән ки, ишеткән бөтен авыл халкы таң калган.* Ә.Баян. *Кулы бәйләнгән һәм аягына да баса алмаган Стакайны күргәч, алар бөтенләй таң калдылар.* И.Хуҗин. **Таң кату** *к.* **таң калу**. *Диләрә Илалетдинова дигән матур тавышлы, нәфис-нәзакәтле җырчының да махсус музыка белеме юк, әмма моңына таң катарлык!* Әлмәт таңнары

**ТАҢГЫ** *с.* Таң вакытында була торган, таңдагы, таң вакытындагы. *Ютәл белән уятмаска иде Гөләпләрнең таңгы сак йокысын...* Зөлфәт. *Тик күзләрен ачасы килмәде, телефон аша таңгы сөйләшү аның миен айкый, йөрәген кискәли иде.* Х.Мөдәррисова

**ТА́Ң ЙОЛДЫЗЫ** *и.* Таң алдыннан аеруча яхшы күренә торган Венера планетасы; Чулпан. *Таң йолдызы калыкмаган әле. Ләкин вакыт соң инде.* Г.Әпсәләмов

**ТАҢКУЧАТ** *и. этн.* 1) Мишәрләрдә кияүгә чыгучы кызның туган йортыннан китәсе көннең таңында дус кызлары белән бергә туган йорты белән саубуллашу җыры җырлау йоласы. *Туйлар узган саен таңкучатта катнашучы кызларның саны азая барган. Чөнки инде «тормышлы» хатыннар таңкучатка килеп йөрмәгәннәр.* Р.Әхмәтьянов

2) Шул йола буенча җырлана торган җыр. --- *сыктаулар үзләренең туй йоласындагы ояларын югалта башлыйлар. Шул ук таңкучатның да соңыннан теләсә кайчан, туй дәвамында башкарылуы бик ихтимал.* Р.Мөхәммәтҗанов

**ТАҢЛАНУ** *ф.* 1) Гаҗәпләнү, таң калу. *Тиргәшчегә тыңләшмә, талашчыга таңланма.* Әйтем

2) Соклану. *Язачак сүзне үз телебез илә генә матур итеп, кеше яратып, таңланып тыңларлык итеп язу бер дә күренмидер.* Шура. *Сүзе шулдыр, үзалдында сөйләнәдер таңланып: «Кичә кызым кайгылы иде, бүген йөри аңланып».* Г.Рашиди

**ТАҢЛА́У** *ф. иск.* 1) Сайлау, сайлану, талымлау. *Таңлаган [кыз] тазга калыр.* Мәкаль. *Сылу таңлап кочармын.* Дастан

2) Гаҗәпләнү, шаккату; соклану. *Ки икесене күреп таңладылар. Тәгаҗҗеп берлә башын ыргадылар.* Мәҗлиси

**ТАҢНАН** *рәв.* Бик иртә, таң белән. *Көн дә таңнан шунда юнәлә, көнозын эсседә дә, салкында да шул Озынталда ята.* Р.Камал. *Балачакта алар, әнигә ияреп, мәктәпкә китә, мин дә таңнан торып утырып, китапларны кулыма алып укырга тырыша идем.* Э.Сәлахова

**ТА́Ң СУЫ** *и. этн.* 1) Таңнан, кеше уянмас борын чишмә, кое кебек табигый чыганактан алынган, сөйләшмичә,

дога укып алып кайтылган, йолаларда файдаланылган, шифалы дип саналган су. *Иртүк торып, чишмәгездән Алып кайт син таң суы, Сөттәй битләреңә төшсен Җитмеш таңның алсуы.* Ш.Галиев. *Кояш чыгып, иң беренче нурлары су өстенә төшкән вакытта, күз тиюдән, төрле авырулардан дәвалау һәм өшкерер өчен, таң суы алалар.* И.Закирова

2) Таңда яки таң атмас борын җыеп алынган, шифалы дип саналган чык

**ТАҢСЫНУ** *ф. сир.* Таң калу, нык гаҗәпләнү; соклану, мөкиббән китү. *Күпме таңсынып карасаң да, бар матурлыкны бәяләп бетереп булмастыр.* Б.Камалов

**ТАҢ-ТАМАША** *җый. и.* Бик гаҗәп хәл, күренеш, вакыйга, хәйран калырлык нәрсә

◊ **Таң-тамаша(га) калдыру** Таңга калдыру, гаҗәпләндерү; нык гаҗәпләндергән нәрсә булу. *Болгарскаяның әби-Галчиха ролендәге осталыгы бөтенләй таң-тамашага калдырды.* Ш.Әхмәдиев. **Таң-тамаша(га) калу** Таңга калу, хәйран калу, гаҗәпләнү. *Илгизәрләр үз йортларына, үз илләренә кайтып, Болгар иле, Алтын кала, Алмас хан сарайлары турысында таң-тамаша калып сөйлиләр, тыңлаучыларның исләрен китәрәләр иде.* Ш.Әхмәдиев

**ТАҢ-ХӘЙРАН** *җый. и. к.* **таң-тамаша**

◊ **Таң-хәйран калдыру** *к.* **таң-тамаша(га) калдыру**. *Аның талчыбыктай зифа буе, озын кара чәче, назлы күз карашы һәм сүзләре, тагын да әллә нәрсәләре, әллә нинди гүзәллекләре мине таң-хәйран калдырып кына түгел, хәтта һушсыз итәләр.* Ф.Яхин. **Таң-хәйран калу** *к.* **таң-тамаша(га) калу**. *Хакыйкый вакыйгаларның бөек шигырь-җыруга әверелүенә ул таң-хәйран калып шашкан иде.* Р.Батулла

**ТАҢЧЫ** I *и. сир.* Сокланучы, мөкиббән китеп, сокланып һәм хуплап караучы кеше. *Барча әхрары мәхәббәт миннән уңда зан итәм; Кайда Фәрһат белән Мәҗнүн! Мин аларның таңчысы.* Г.Тукай

**ТАҢЧЫ** II *и. тар.* Таңчылык тарафдары. *Таңчылар, --- рус народниклары кебек, авылларга йөреп, митинглар үткәрәләр, крестьяннарга сәясәт турында газеталар укыйлар, шәхес азатлыгы һәм җир мәсьәләләрен аңлаталар, үз хокуклары өчен тартышырга өндиләр.* Р.Ганиева. *Таңчылар сәясәтен нигездә хупласа да, Тукай, уйламыйча, теләсә нинди идеягә ортодоксларча, кырмавык кебек ябыша торган, кuштаннар дәрәҗәсенә төшә торган зат түгел, аның һәр шәйгә үз бәясе, үз мөнәсәбәте бар.* Т.Галиуллин

**ТАҢЧЫЛЫК** *и. тар.* 1905–1911 елларда татар эсерларының татарларның милли, сәяси һәм рухи мөстәкыйльлеге фикерен алга сөргән, рәсми органы «Таң йолдызы» газетасы булган иҗтимагый-сәяси оешма. *Гаяз Исхакый иҗатының «таңчылык» дәверендә дә (1905–1911), «Таң йолдызы» газетасы битләрендә һәм әдәби әсәрләрендә халыкчылык мотивларын яктыртуга зур урын бирелә.* Р.Ганиева. *«Таңчылык» чорында ул [Г.Исхакый] социализм идеяләре белән саташып йөри, эсерлар алга сөргән террорчылык белән дә мавыгып ала.* Т.Галиуллин

**ТАП** I *и.* 1) Берәр өслекнең төсе, тоны, яктылыгы белән аерылып торган өлеше. *Бит урталарына кызыл таплар чыккан бер чандыр кеше, кепкасын учына йомарлап, трибуна өстендә озак җилкенде.* И.Гази. *Маңгаенда аның [айгырның] уч төбедәй генә ак табы – йолдызы бар.* Н.Фәттах

2) Берәр өслектә нәрсә дә булса агып, түгелеп буялган, пычранган урын. *Әйе, бала тапны кырып алмак була, Нәтиҗәдә бөтен өсте каймак була.* З.Мансур. *Ак эскәтердә лимон табы кебек кенә кояш беленеп тора ---.* К.Кәримов

3) Пыяла яки ялтыравык өслектә кул, бармак эзе. *Пенснәне кесәсеннән алып, ак яулык илә сөртеп, күзлекнең бер дә табы калмаганлыгыны ут яктысына тотып, бик дикъкатьләп карап кигәннән соң, --- алтыннарны тотып, әйләндереп карап тамаша кыйлырга кереште [ул].* Г.Камал

4) *күч.* Оятлы итә торган нәрсә; кимчелек, җитешсезлек; хата. *Соңгы тамчы каным тамса, тамсын, Тик антыма таплар кунмасын!* М.Җәлил

◊ **Тап төшерү** Яхшатка, намуска, данга зыян китерү, пычрату. *Шунда ул, яралы булса да, иптәшләрен ташлап китәргә хакы юклыгын, әгәр дә ташлап китсә, намусына гомер буе юып ала алмаслык тап төшерүен бик яхшы аңлады.* Г.Әпсәләмов. *Әйе, Бөек Ватан сугышы чорларында үзләренең исемен тутыкмас данга күмгән совет хәрби диңгезчеләренең матур традицияләренә мыскал да тап төшерергә ярамый.* А.Хәсәнов. **Тап төшү** Кемнең дә булса намусы пычратылу, абруе төшү. *Хәмидә апаның намусына да тап төшмәс, тормышы да җимерелми калыр иде.* В.Нуруллин. *Сездә калсам, синең намуслы, саф исемеңә тап төшүе бар иде.* А.Гыйләҗев

**ТАП** II *кис. диал.* Нәкъ. *Аксыл сары елкылдаулы чәче тап урталай ике якка аерылган, ике күзе күк касәседәй фирүзә зәңгәр [аның].* Р.Батулла

**ТАП-** *кис.* Кайбер сүзләр алдыннан килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый торган кисәкчә. *Авыл советы катнашы белән төзелгән бу семьяда нәкъ өч айдан соң тап-таза бер малай дөньяга килде.* М.Мәһдиев. *Кабартма кебек матур кулы урта бармак сөяген тырпайтып йомарлана да, зәһәр сүздән соң шул урта бармак сөяге синең тап-такыр баш түбәңә чүки.* Р.Батулла. *– Озак кигән эшләпә башка тап-таман була дигәндәй, без менә хатын белән чөкердәшеп яшибез, – диде Миңнехан, киң күңелле булырга тырышып.* В.Имамов

**ТАПАГЫЧ** *и.* 1) Кайбер төр яшелчәләрне тапау өчен махсус пычагы яки балтасы булган җайланма. *«Бусы – электр чөгендер тапагычы, үзем ясадым», – ди ул, тимер «чиләк»кә күрсәтеп.* Ватаным Татарстан

2) Чалгы тапау өчен кечкенә сандал. *Карт, тапагычы янындагы кечкенә генә печән өеменә сузылып, саплары гына күренеп торган чалгыларның берсен кулына алды.* М.Хәсәнов

**ТАПАМА** *и.* **1.** Тапалган масса. *Салам тапамасы*

**2.** *с. мәгъ.* Тапалган хәлдәге, тураклanган, вакланган. *Тапама печән*

**ТАПАС** *и. гр.* 1) *к.* **топаз**. *Электә бизәнгеч буларак болгарлар һәм*

*татарлар арасында фирүзә, сердолик, тапас, --- шулай ук гәрәбә һәм энҗе-мәрҗән кулланылган.* А.Тимергалин

2) *диал.* Муенса, мәрҗән. *Алып бирермен тапас, Матур булырсың таккач.* Җыр

**ТАПА́У** I *ф.* 1) Тамыразык, салам, камыш, агач, чыбык-чабык кебек нәрсәләрне балта яки тапагыч белән ваклау, турау. *Ай кыралар урманны, нык кыралар: күпме тырпаешып утырган төпсә, егылган яки киселгән агач, тапап ыргытылган чыбык-чабык!* Ә.Әминев. *«Кош-кортлар, сарык бәтие, бозаулар тиз үссен дисәгез, --- кычыткан җыегыз, аны тапап бирегез, ә калганын, бәйләп, абзар башына кибәргә куегыз», – диләр иде.* Безнең Чирмешән

2) Бик вак итеп кисү, ашау (бөҗәкләр тур.). *Гайбәт, көя күбәләге төсле, гаиләнең татулыгын да тапый иде.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Борчу, газаплап тору. *Болай да йөрәкне уй тапый.* Р.Габделхакова

**Тапап алу** Тиз генә тапау

**Тапап бетерү** Тәмам, бик нык тапау; тапауны тәмамлау. *Шунда ук кылычы белән диюнең башын чабып төшерә, гәүдәсен тапап бетерә.* Әкият. *Алар эш урынына барып җиткәндә, кызлар, килеп, бер чыршыны тапап бетергәннәр иде инде.* Г.Гобәй

**Тапап тору** Әледән-әле яки берөзлексез тапау; әле, хәзер тапау. *– Җәмига түти, олы башың белән интегеп йөрмәсәң дә була, анда бер чүмәлә печән калды инде, мин ыргытырмын, Гөлтүташ тапап торыр, төярбез әле, – диде Зөлмир.* З.Мурсиев

**Тапый төшү** Тагын да ныграк тапау

**ТАПА́У** II *ф. к.* **таптау** I (*6 мәгъ.*). *Чаң-чоң чалгы тапыйлар. Халык печәнгә әзерләнә.* А.Хәсәнов

**ТА́П БУЛУ** *ф.* 1) Очрау, очрату; туры килү; юлыгу. *Батырҗан Айсылуның җырлавына соклана, урман чәчәкләрен җыеп бүләк итәргә тели, шул вакытта янар чәчәккә тап була.* А.Гадел. *Чыганакларга карасак, күп кенә борынгы күрәзәләрнең һәм фикер ияләренең, --- җир йөзенә нindидер бер куәтле каһарман килеп, адәмнәрне котқарачагы турында әйткән сүзләренә тап булабыз.* А.Тимергалин

2) Дучар булу. *Аргымактай егет ялчылыкка Ярлылыгы белән тап була.* Бәет

**ТАПЁР** *и. фр.* Рестор采ннарда, бию кичәләрендә уйнаучы музыкант; тавышсыз кинофильмнарны күрсәткәндә уйнаучы пианист. *13 яшендә инде ул кинотеатрда тапёр, ягъни музыкант булып эшли, анда композиция тудыруның беренче тәҗрибәләрен ясый, тавышсыз кино темаларына импровизацияләр тудыра.* М.Хәсәнов. *Ә тапёрның вазифасы тавышсыз кинолар күрсәтелгән вакытта караңгы залда төрле көйләр башкарудан гыйбарәт икән.* Мәдәни җомга

**ТАПИР** *и. фр. зоол.* Тактояклылар семьялыгыннан тропик урманнарда яшәүче кечерәк хортумлы эре имезүче хайван. *Биредә коңгызлар, попугайлар, капибара, тапир яшәячәк.* Шәһри Казан

**ТА́П КИЛҮ** *ф.* 1) *к.* **тап булу**. *Куе ботаклы агач ябалдашына тап килгән берәү вак-төяк тән җәрәхәтләре белән котылып калган.* А.Гыйләҗев

2) Таман, урынлы, килешле булу. *Зәлифә ак халаттан бигрәк тә чибәр икән: киеме --- тап-таман булып, туташның нәфислегенә тап килеп кенә тора.* З.Мурсиев

**ТАПКЫР** I *бәйл.* **1.** 1) Саннар яки күләмне, чаманы белдергән сүзләр белән янәшә килеп, «мәртәбә, кат, кәррә» дигән мәгънәне бирә. *Үзебезне берничә тапкыр бүләкләделәр.* А.Алиш. *Беренчедән, ул секундка миллионнарча математик һәм логик гамәл башкара, ягъни бездән күп тапкыр җитезрәк.* А.Тимергалин

2) **тапкырлар** *ритор.* *Азмы, ничә* сүзләре белән килеп, «бик күп»; «каткат» мәгънәсен белдерә. *Азмы тапкырлар Хәлил Гөлгенәне ата каз талый башлагач коткарып калды.* Г.Гобәй

3) **тапкырын, тапкырына, тапкырында, тапкырыннан** *диал. тарт. форм.* Нәрсәнең дә булса янәшәсендә, турысында, каршысында. *Мичнең казан тапкырында кош оясы кебек түгәрәкләп ясалган бер урын бар.* М.Гафури

**2.** *и. мәгъ.* Эшнең башкарылу санын белдерә; кат, мәртәбә, кәррә, дәфга. *Без инде тарының бишенче тапкырын утадык.* Г.Бәширов. *Ләкин алар Атлантиданың мәйданын хисаплаганда 10 тапкырга ялгышканнар ---.* А.Тимергалин

**ТАПКЫР** II *с.* **1.** 1) Дөрес җавапны, үткер сүзне тиз таба торган, зирәк. *Бу илнең иң тапкыр кешесе син идең бит әле!* Н.Исәнбәт

2) Бик урынлы, бик үткер әйтелгән (сүз, җавап, фикер, киңәш һ.б.ш. тур.). *Тырыш һәм тапкыр сүзле яшь педагогны озакламый яшьләрнең район комитетына чакырып, бүлек редакторы итәләр.* М.Кәримов

**2.** *рәв. мәгъ.* Урынлы, үткер итеп. *Син бик тапкыр әйттең.* Г.Бәширов

**3.** *и. мәгъ.* Оста сөйләшүче, бик тиз фикер йөртүче, үткер җавап бирә белүче кеше. *Отканга – мәкаль, тапкырга – табышмак.* Н.Исәнбәт. *Тапкырлыкта җиңгәч барлык тапкырларны, Кукраеп Исәнбәткә килгән хуҗа.* З.Мансур

**4.** *хәб. мәгъ.* Туры килә торган, ярашлы, муафикъ. *Шушы сыйфатларны автор яңа геройга тапкыр дип күрергә теләде.* Г.Халит

**ТАПКЫРЛАНУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тапкырлау**. *Тик нигә соң ике чыкмый Тапкырланса бергә бер?* Р.Корбан. *Гаиләдә ике укучы икән, барлык чыгымнар да икегә тапкырлана дигән сүз.* Мәйдан

2) Билгеле мәртәбәгә, берничә тапкырга арту, күбәю, ишәю. *Ә суының даһи көзгесендә тапкырлана һәр төс меңнәргә.* Р.Харис

**ТАПКЫРЛАНУ** II *ф.* Тапкыр (II) булып китү, зирәкләнү. *Кәбул Хәйбуллович тагын да кимсенде, шуңа да сәркәтип кызның бу кадәр тапкырланып маташуын өнәмәде.* Ф.Яхин

**ТАПКЫРЛАП** *рәв.* Тапкырлау билгесе рәвешендә (чигү тур.). *Мәдәнә авылыннан З.Т. Айнетдинова (1950) яшь вакытында тапкырлап чигү белән мавыккан ---.* Милли-мәдәни мирасыбыз. *Юрган сыру һәм чигү эшен (тапкырлап чигү, тутырып чигү, тамбур җөй, мережкалау һ.б.) шушында үзләштергән була ул ---.* Шәһри Казан

**ТАПКЫРЛА́У** I *ф.* 1) *мат.* Бирелгән бер санны икенче бирелгән сан белдергән берәмлек кадәр арттыру. *Ул,*

*бик күп тиеннәрне бергә кушып, зур-зур суммалар туплады, расходларны доходлардан чигереп ташлады, әллә нинди зур саннарны тапкырлады, бүл-де.* А.Алиш. *Ә менә өчкә өчне кушкач алты, өчне өчкә тапкырлагач тугыз була.* Р.Вәлиев

2) Бер сүзне яки берәр төр шөгыльне берничә мәртәбә кабатлау. *Вәли абзый, язган бер сүзен әллә ничә тапкыр авыз эченнән тапкырлый-тапкырлый, хат язды.* Ә.Фәйзи

3) Арттыру, ишәйтү, күбәйтү. *Балта тавышын урман, йөзгә тапкырлап, еракка яңгыратты.* М.Мәһдиев. *Алар халыктан өйрәнергә һәм алган белемнәрен бик күпкә тапкырлап, халыкка кайтарырга тиешләр.* И.Гази

**Тапкырлап алу** Тиз генә тапкырлау

**Тапкырлап җибәрү** Тиз арада тапкырлау. *Шуны инде, законда каралганча, унга тапкырлап та җибәрсәң!* Мәдәни җомга

**Тапкырлап кую** Алдан ук тапкырлау; тиз генә тапкырлау. *Һәм әзрәк арканны кыздырып алу хакына, әлбәттә, хәләл җефетеңне дә ияртергә ниятләсәң, әлеге бәһане икегә тапкырлап куй.* Р.Фәйзуллин

**Тапкырлап тору** Әле, хәзер тапкырлау; гел, һәрвакыт тапкырлау

**Тапкырлый бару** Даими, эзлекле рәвештә тапкырлау

**Тапкырлый башлау** Тапкырларга тотыну. *Корбаннар санына тапкырлый башласаң, коллыкка өләшенүчеләрнең саны гына да илле меңгә барып басадыр.* В.Имамов. *Кыскасы, 1980 сум күләмендә билгеләнгән база тарифын әлеге коэффициентларга тапкырлый башласаң, шактый гына акча чыгарып салырга туры килә.* Татарстан яшьләре

**ТАПКЫРЛА́У** II *и. мат.* Санны, зурлыкны икенче бер са́нча куша барып арттыру гамәле. *Мәсәлән, шул ук «Фәраиз» китабы буенча --- тапкырлау җәдвәлен өйрәнергә була.* М.Галәү. *Көндезләрен, нәкъ башкалар кебек үк, эштә буталам: исәп-хисап эшләре, акча күчерү, юлламалар төзү-санау, алу, кушу, тапкырлау...* Х.Ширмән

**ТАПКЫРЛА́У** III *ф.* Аңлау, төшенү; туры китерү, дөрес, анык билгеләү. *Фронтның кайсы якка киткәнен тапкырлау кыен.* А.Таһиров

**ТАПКЫРЛАУЧЫ** *и. мат.* Тапкырлашучыларның берсе – бирелгән санның ничәгә тапкырлануын күрсәткән сан. *Иң кечкенә уртак ваклаучыны, өстәмә тапкырлаучыны таба белү.* Алгебра

**ТАПКЫРЛАШУЧЫ** *и. мат.* Тапкырлана торган саннарның берсе. *Тапкырлашучыларның урыннарын үзгәртеп карау*

**ТАПКЫРЛЫК** *и.* 1) Тапкыр (II) булу, зирәклек. *Минем аңар каршы ни дип җавап бирергә дә тапкырлыгым җитмәде, эчемнән генә мин: «Аллага шөкер, хәзер минем дә инде бер һөнәрем була башлады бит!» – дип уйладым.* Ф.Әмирхан

2) Оста, тапкыр сүз яки кыланыш. *Яшь татар интеллигенциясе --- купшы хатын-кызлар арасында кайнаша, көлешә, үткерлекләр, тапкырлыклар чәчә иделәр.* Ш.Камал

**ТАПКЫРЧЫГЫШ** *и. мат.* Бер санны икенче санга тапкырлаганнан соң чыккан сан. *Тапкырлаучыларның урынын алыштырудан тапкырчыгыш үзгәрми*

**ТАПЛАНУ** *ф.* 1) Нәрсәнеңдер өстенә тап төшү; таплыга әйләнү. *Чәчәк үсә торган киң болыннар Кеше каны белән тапланган.* Ф.Кәрим

2) *күч.* Рухи сафлыкка, намуска тап I (*4 мәгъ.*) төшү. – *Синең теләсә нинди егет карарлык чибәрлегең, аек акылың, бернәрсә белән дә тапланмаган саф йөрәгең бар, сиңа бәхетне табу җиңелрәк, – ди акыл.* Ф.Яруллин. *Исемебез тапланса да, Аллага шөкер, дөнья дилбегәсе безнең кулыбызда бит.* В.Имамов

**Таплана башлау** Яңа гына таплану; тапланырга тотыну. *Ярмөхәммәт бабасының таплана башлаган йөзенә карады.* Р.Батулла

**Таплана төшү** Берникадәр таплану. *Ак алъяпкыч та атна ахырына берникадәр таплана төште*

**Тапланып бетү** Бик нык таплану. *Журнал теткәләнеп, тапланып беткән.* М.Хәсәнов. *Ишегалдында йод белән тапланып беткән җәймәләр, мендәр тышлары җилферди.* Г.Әпсәләмов

**Тапланып тору** Әле, хәзер таплану. *Кичә булган һәлакәт урыны гына караеп, тапланып тора.* Г.Гыйльманов

**ТАПЛА́У** *ф.* 1) Тап төшерү, таплы итү. *Сөйләп бирде: «Улым белән килենемнең фатирлары бик чиста, бик зур. --- Фатирларын таплармын дип куркып, өч көн бүлмәмнән чыкмый утырдым», – дип әйтә [ул].* З.Мурсиев

2) *күч.* Тап I (*4 мәгъ.*) төшерү. *Инде хәзер, болайга киткәч, яшереп калу, әйтмәү аның өчен мең мәртәбә авыррак булачак, Гөлзада белән аның намусын кешеләр алдында таплаячак иде.* Ф.Садриев. *Алар «әхлак» сүзенең бәясен төшерә, аклыгын таплый.* З.Мурсиев

**Таплап бетерү** Бик таплау. *Тәрәзә араларында, килеп керүчеләргә кырыс караш ташлап, өстен чебеннәр таплап бетергән патша һәм патша хатыны сурәтләре эленеп тора.* М.Галәү

**Таплап тору** Даими яки әледән-әле таплау; әле, хәзер таплау. *Юкса Ирекнең: «Минеке түгел ул бала!» – дип кычкыруы гел колак төбендә яңгырап, намусын таплап торды.* Р.Шәрипова

**ТАПЛЫ** *с.* 1) Таплары булган, тап төшкән. *Яңа чагындагы төсе уңып, кырыкмаса-кырык җиреннән тишелгән таплы клеёнка эскәтер өстендәге кәгазьләр арасыннан шәм төпчеге һәм күмерле сургыч таякчыгы күренеп тора.* М.Галәү. *Эче тулы зар булса да, тәмәке сасысына туенган бу ямьсез бинада кыршылган таплы өстәл янында тупас ирләрнең йонлы колагына түгә торган түгел иде.* М.Маликова

2) *күч.* Саф, эчкерсез, гөнаһсыз түгел. *Шунысы шаккатыра: мин бер генә матур минутымны да хәтерләмим. Алар барысы да таплы, нәфрәтле, пычрак.* З.Мәхмүди

**ТА́ПОЧКА** *и. рус сөйл.* Үкчәсез һәм артсыз җиңел йомшак аяк киеме; башмак, чүәк. *Алмаш-тилмәшкә ике ситсы күлмәге, чәч үрергә лентасы, аягына арзанлы ак тапочкасы бар.* Г.Әпсәләмов. *Мин моңа игътибар иттем: бу инде кич чыгар өчен киенеп куйган – ак кофта, үтүкләнгән юбка, аягында апак брезент тапочкалар.* М.Мәһдиев

**ТАПСЫЗ** *с.* 1) Табы булмаган, чиста. *«Шулкадәр майга батырмасагыз*

*булмас идеме?» – дип, дәфтәрләрне, тапсыз почмагыннан тотып, җирәнә-җирәнә өскә күтәрделәр.* Ф.Җамалетдинова

2) *күч.* Чиста, пакь, эчкерсез, керсез. *Туган халкыбызның тапсыз намусы өчен актык сулышыбызгача көрәшербез.* Ш.Маннур

**ТАПСЫЗЛЫК** *и.* Тапсыз булу; пакьлек, сафлык

**ТАПТАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **таптау** I. *Кеше затының табаны астында күпме генә тапталмасын, җир-ана барыбер бөек!* Р.Низамиев

2) Юл, сукмак һ.б.ш. күп йөрү нәтиҗәсендә такыр һәм шома булып китү. *Кораңгыш тапталмаган сукмак буйлап салмак кына юырта башлады.* Р.Батулла. *Андый кәшәкә таягы йомры тупны «учлап» эләктереп ала да тапталып, шомарып беткән урам буйлатып, каршы капкага кадәр шудырып алып китә.* Г.Гыйльманов

3) Аяк, транспорт, авыр әйбер астында калып имгәнү яисә һәлак булу. *Җәй уртасында кинәт кенә Сабирның очраклы рәвештә машинага тапталып үлүе авылыбыз өчен зур кайгы булды.* Ә.Сафиуллин. *Яралылар тояк асларында калып таптала.* Р.Сәгъди

4) Нәрсәдер өстеннән ат, транспорт үтү нәтиҗәсендә сыну, уалу, ваклану. *Пыяла кисәкләре чытыр-чытыр тапталып кала.* И.Гази

5) *күч.* Юкка чыгарылу, изелү, кимсетелү, әрәм ителү. *Мин тапталган бер көтүче идем. Дөнья түгел, гүр көтүче идем.* Ә.Ерикәй. *Азмыни тапталган патшалар, корольләр, шаһлар, солтаннар.* Т.Миңнуллин

6) *күч.* Күп кабатлану нәтиҗәсендә үтемлелеген югалту, тәэсир көче бетү (табышмак, әйтем, мәкаль, рифма, әдәби алым һ.б.ш. тур.). *Хәзер ул бик таушалган, тапталган образга әйләнеп китте.* Н.Нәҗми. *Сәясәт, диңгез экзотикасыннан качарга теләвемнең сәбәбе көчне иң тапталган, иң чәйнәлгән сюжетта сынап карыйсы килү иде.* Ф.Яруллин

◊ **Тапталган сукмак** *к.* **тапталган юл**. *Аны әзер темалар, тапталган сукмаклар аз кызыксындыра.* Ф.Хатипов.

**Тапталган юл** Искергән, оригинальлеген югалткан алым, ысул. *Хәзер дә спектакльне тапталган юл буенча куеп булыр иде, әмма бүгенге көн үзе режиссёрдан яңа алымнар таләп итә ---.* Өмет

**Таптала бару** Торган саен тагын да ныграк, күбрәк тапталу. *Әрнү, җан газабы машина тәгәрмәчләре астында таптала барды.* Сөембикә

**Таптала төшү** Берникадәр тапталу; тагын да тапталу. *Тагы да түрдәрәк, таптала төшкән балчык өеме өстендә, аякларын як-якка җәеп, шыңшыйшыңшый бер кыз ята.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тапталып бетү** Бик нык тапталу. *Чебиле аякларына нимес балалары аягыннан күчкән, табаннары тапталып беткән иске трофей сандали эләктереп алган Сәгъдәт җай гына урам аша чыкты.* А.Хәлим. *Күпереп үскән үлән тапталып беткән.* Г.Гыйльманов

**Тапталып килү** Билгеле бер вакыттан бирле тапталу. *Шуның өчен авылларда хатын-кызларның хокуклары да аяк астында тапталып килә.* Һ.Такташ

**Тапталып кую** Тиз арада тапталу. *Күп таптанып торсаң, тапталып та куярсың әле.* А.Хәлим

**ТАПТАЛЫШ** *и.* Тапталу күренеше. *Мәскәүдә аның табуты куелган бина янына үтү өчен тапталыш, кырылыш булган, берничә кеше шунда кысылып үлгән.* А.Расих

**ТАПТАНУ** *ф.* 1) Аякларны алмаштилмәш бер урында баскалау. *Аптыраудан гаҗиз калган ир нишләргә белмәде: әле тирләп чыккан маңгаен сөртте, әле гасабиланып кулларын угалады, баскан урынында таптанды.* Ф.Хуҗин. *Нишләп бусага төбендә таптанасың, үскәнем?* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Алга китеш, үсеш-үзгәрешләр булмау, бер төрле хәлдә тору. *Үзгәрешләр юк, һаман таптанабыз шунда*

**Таптана башлау** Таптанырга тотыну. *Атлар да бер урында таптана башлады.* Р.Батулла. *Кеше дә үз юлыннан, кыйбласыннан тайпылса, бер урында таптана башлый, бутала, адаша, ялгыша.* Р.Кәрами

**Таптана бирү** Бернигә карамый таптану. *Кызчык кыюсыз гына бер урында таптана бирде.* С.Гаффарова. --- *Һашим, баскан җирендә таптана биреп, абыйсының җилкәсенә кулын салды ---.* Т.Гарипова

**Таптана тору** Беркавым таптану. *Таптана торгач, арырак тагы да гаҗәбрәк бер нәрсәгә күзем төште.* Т.Әйди

**Таптанып алу** Аз гына, кыска гына вакыт таптану. *Хәлим --- баскан урынында таптанып алды.* Г.Бәширов. *Айгыр, пошкырып, алгы уң аягының дагалы тоягы белән так-ток китереп, такта идәнгә тибә, урынында таптанып та ала.* З.Зәйнуллин

**Таптанып кую** *к.* **таптанып алу**. *Өшегән кулларын чатыр-чотыр килеп яна башлаган учак җылысына сузып чүгәләгән генә иде [ул], аты никтер урынында таптанып куйды.* Ш.Шәйдуллин. *Карашы белән очкыннар чәчеп, ул бер урында сабырсыз таптанып куйды.* Р.Вәлиев

**Таптанып тору** Даими таптану; әле, хәзер таптану. *Татар эстрадасында юмор үсештә, ул бер урында туктalып, таптанып тормый.* Кәеф ничек?

**ТАПТАТУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **таптау** I. *Нихәтле игенне таптаткансың!* Г.Әпсәләмов

2) Өстенә басып, таптап үтәргә ирек бирү, көч кую. *[Насыйп:] Әптери, әйбер таптатасың, күк бияңне уңгарак ал!* Г.Ибраһимов. *Таптатма син дошманнардан әнкәңнең каберен.* Ә.Исхак

3) Ат белән, транспортта өстеннән үтеп имгәтү яисә үтерү. *Шуның өстенә тагын кеше таптатканны да белсә [Роза]...* В.Нуруллин. *Таң тишегеннән «мәтәлчегеңне» кабызып, бөтен авылны дер селкетеп, бәпкәләр таптатып йөрмәскә.* А.Тимергалин

4) Нәрсәнең дә булса өстеннән ат, үгез йөртеп яки транспортта үтеп ваклату, издерү яисә тыгызлау, бастыру. *Атларны бер түгәрәктә әйләндереп киндер таптаталар.* Ш.Галиев. *Бу бүлекчәдә без өч көндә базга мең тонна сенаж салдык, таптатып, өстен плёнка белән яптык.* Идел таңнары

5) *күч.* Басып алырга, җәберләргә, мыскылларга мөмкинлек бирү. *Без дошманнан таптатмабыз Сөекле*

*илебезне.* Җыр. *Кызлар, хатыннарның саф намусын Таптатып, без рисвай булыйкмы?* Ф.Кәрим

**Таптата бару** Эзлекле рәвештә даими таптату. *Әзер массаны таптата бару*

**Таптата башлау** Таптатырга тотыну. *Атын сикертеп, каршында үкерешкән кешеләрне бәрә-ега таптата башлады [ул], мәтәлеп киткән бер кешене аркылы сикергәндә, кайсыныңдыр көчле кулы күсәк белән атның алгы аягына сукты.* И.Гази

**Таптата төшү** Тагын да күбрәк, яхшырак, ешрак таптату

**Таптатып алу** Тиз генә таптату

**Таптатып бару** Даими, эзлекле рәвештә таптату. *Аны К-700 тракторында Анатолий Горшков таптатып бара.* Якты юл

**Таптатып бетерү** Күпләрне таптату; бик нык таптату; тулысынча таптату. *Тимер юлда бала-чаганы таптатып бетерер әле.* А.Гыйләҗев. *Мал йөри торган бөтен болынны трактор белән таптатып бетергәннәр.* Р.Вәлиев

**Таптатып тору** Даими таптату; әле, хәзер таптату. *Ә биредә көндез ике, төнлә белән бер трактор үләнне чиратлап таптатып торалар.* Дуслык

**ТАПТА́У** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өстенә басып йөрү. *Аяклар, салмак атлап, урамны таптадылар ---.* А.Алиш. *Без шул алтынның өстеннән таптап йөрибез, әмма берни күрмибез.* Г.Әпсәләмов

2) Игенне, үләнне аяк яки тәгәрмәч белән басып җиргә егу, яткыру. *Агачны сындырма, яшелчәне таптама, булганыннан теләгәнеңчә сыйлан.* М.Хуҗин. *Умарталыкта үскән яшел үләнне таптап, машина китеп барды һәм тиздән урман караңгылыгына кереп югалды...* З.Зәйнуллин

3) Басу, бастыру, тыгызлау. *Ул без биреп торган печәнне эскерт башына җәйлап салып таптый*

4) Аяк белән басып пычрак эзләр калдыру, пычратып бетерү. *Кая керәсең юган идәнне таптап!* Г.Бәширов

5) Өскә басып үтү, имгәтү, сыту, вату, изү. *Атыннан төшкәнлеген, үзен башка атлар таптап китәрлеген дә онытып җан-фәрманга чапканда, кемдер аны якасыннан эләктереп алды, читкә сөйрәп чыгарды.* М.Галәү. *Халык берсен-берсе таптап кача.* Р.Батулла

6) *диал.* Чалгы яки пычак йөзен чүкеп юкарту юлы белән үткенләү; чүкү. *Чалгы таптау*

7) *күч.* Кайда да булса еш булу, кайдандыр күп мәртәбәләр үтү. *Чөнки бала вакыттан ук Габденнасыйр бу юлны күп таптаган, ат белән генә түгел, җәяү дә күп йөргән.* М.Гали. *Бөгелмә якларын да күп таптадым.* Ф.Яхин

8) *күч.* Кайда да булса озак, күп йөрү. *Мин сугышта биш ел кеше иле таптадым, үзебезнең туган яктан да матур ил юк, Фатыйма балам, көн дә төшләреңә кереп, саташып үләр идең.* З.Кадыйрова

9) *күч.* Кемнең дә булса хокукларын, теләкләрен һ.б.ш.ларны санга сукмау. *Синең дөрес фикерләреңне, гаделлегеңне дөнья гаделсезлеге таптап үтә бит, шуны аңламыйсыңмыни?!* З.Хәким. *Чыңгыз әманәт итеп калдырган «Яса» кануннарын таптап, Алтын Урда нигезен әүвәл кем какшатты?* В.Имамов

10) *күч.* Мыскыллау, хур итү. *Аналарның намусларын таптап, Илебезнең изге җирен таплап, Халык милкен талап алучы.* Ф.Кәрим. *Курыкма, үзең кеше булып калсаң, кантур күселәре генә горурлыгыңны таптый алмас.* Җ.Юныс

**Таптап бетерү** Бик нык таптау. *Урылмыйча ятып, терлекләр таптап бетергән ашлык та аныкы була иде.* М.Галәү. *Бөтен бүлмәләрне таптап бетерделәр.* З.Мәхмүди

**Таптап йөрү** Даими таптау; әле таптау. *Ошап китте бугай моңа минем пункт тирәсен таптап йөрү.* Р.Гаязетдин

**Таптап китү** Көтмәгәндә таптау. *Арты белән чигенә барып, Ханбал кемнедер таптап китә язды.* Ф.Яхин

**Таптап кую** Алдан таптау. *Кемдер балта саплаган, кемдер чалгысын печән өстенә таптап куйган.* В.Нуриев. *Узган ел тамыразыклар үскән урыннарда туфракны кимерүчеләрдән саклар өчен таптап куярга кирәк.* Яшел Үзән

**Таптап тору** Даими яки әледән-әле таптау; әле, хәзер таптау. *Әти белән абый богылларны күтәреп салалар, мин таптап торам.* Ф.Садриев. *Шул ук көнне ферма янында силос базын таптап торучы куәтле бульдозер, коены күмеп, урынын җир белән тигезләп куйды.* И.Шиһапов

**Таптап чыгу** Барысын да таптау, тулысынча таптау. *Менә, ниһаять, Грузияне дә таптап чыктык.* Ф.Баттал

**Таптый башлау** Таптарга тотыну. *Нотык тоткан бәндәгә ләгънәт сүзләре яудырасы, аны өстерәп төшереп таптый башлыйсы урында, гавам каһкаһә белән шаркылдап көләргә тотынды.* З.Мәхмүди

**Таптый бирү** Бернигә карамый таптау. *«Хәтәр» машиналар кешеләрне ничек таптаган булсалар, һаман шулай таптый бирәләр ---.* Татарстан яшьләре

**Таптый тору** Әлегә таптау; әледән-әле таптау. *Кешелек җәмгыяте шуларны уйлап ятканда, безнең авылның Әсхәдулла абзый егерме чакрымлы Арча юлын таптый торды ---.* М.Мәһдиев

**ТАПТА́У** II *с. диал.* 1) Такыр (җир, басу тур.)

2) *и. мәгъ.* Такыр басу. *Үсәсе чәчәк таптауда да үсә.* Мәкаль

**ТАПТАШ** *и.* Таптау күренеше. *Мәктәптә тагы кичәге тыгынлык, шау-шу һәм тапташ иде.* Г.Ибраһимов

**ТАП-ТОП** *иярт.* Каты-каты басып йөргәндә, йөгергәндә чыккан тавышны белдерә. *Кемнәрдер тап-топ чаба башлыйлар.* А.Гыйләҗев

**ТАП-ТОП ИТҮ** *ф.* Тап-топ иткән тавышлар чыгару

**ТАПТЫРУ** *ф.* 1) Көчләп нәрсәне дә булса табуны таләп итү. *Таптырыгыз моңардан Иргалине дә, аннан соң җанын җәһәннәмгә җибәрегез!* Ф.Бурнаш. *Гаиләсен алып шәһәрдән качса, аны хан барыбер табачак һәм казнаны таптырачак.* В.Ильясов

2) *күч.* Бик үтенеп, сорап теңкәгә тиеп бетү. *[Гәрәй:] Кызлар җыр таптырып аптырата яздылар бит.* М.Фәйзи

3) *күч. сөйл.* Әйткәнне раслату, дәлилләргә мәҗбүр итү. *Кем көри [акчаны]?!! Таптырам, судка бирәм, ник пычрак атасың?..* Ф.Садриев

**Таптыра башлау** Таптырырга тотыну. *Пәһлеван шул тегәрҗәп белән Җайтабаровның ярасын тегеп куйды*

*да җеп өзәргә кайчы таптыра башлады.* Г.Афзал. *Әнкәсеннән сине таптыра башлаган.* Г.Гыйльманов

**Таптырып тору** Даими яки әледәнәле таптыру; әле, хәзер таптыру. --- *Сине белемең эзләнергә, яңаны табарга ымсындырып, этәреп, куалап, ниһаять, таптырып тора.* М.Хуҗин

**ТАПЧАН** *и. кыт.* Өч ягы терәлеп утырыр өчен артлы итеп эшләнгән, бер ягы аяк киемен салып менеп утырыр өчен ачык калдырылган, һәм ятак, һәм табын итеп кулланыла алган аяклы киң сәке шикелле агач җиһаз. *Алачык эчендәге өч аяклы өстәлне һәм шыгыршагыр тапчанны элеккеге хуҗалар калдырган.* А.Хәсәнов. *База тапчаннары каты булса да, малайлар ышыкта, куркынычсыз җирдә рәхәтләнеп йоклыйлар.* А.Тимергалин

**ТАПШЫРГЫЧ** *и.* **1.** Төрле сигналларны, сөйләмне, сурәтне һ.б.ш.ларны ерак араларга тапшыру аппараты. *Шул вакыт тапшыргычтан капитанның тавышы ишетелде, ул биредәге барлык космонавтларны корабльгә чакырды.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Төрле сигналларны, сөйләмне, сурәтне һ.б.ш.ларны ерак араларга тапшыра торган. *– Ничек уйлыйсыз, Харис әфәнде, сезнең фатирга нинди дә булса тыңлау аппараты, тапшыргыч аппарат куйган булулары мөмкинме? – дип сорадым мин ---.* Н.Акмал

**ТАПШЫРУ** I *ф.* 1) Килешенгәнсөйләшенгән, булганны яисә йола, закон буенча бирелергә тиешлене бирү. *Бүген без бик күп алдынгыларга кыйммәтле бүләкләр тапшырдык.* Ф.Баттал

2) Берәр җиргә килешенгән шартлардан озату, бирү. *Колбасаны сатарга ярамас, ресторанга гына тапшырырбыз.* Р.Рахман. *Дәүләткә иген тапшыру*

3) Берәр кешегә йөкләмә бирү, эш кушу. *Кичә ястү намазында Коръән укуны, сафсата, кулак Хәйригә тапшырып, бик зур ялгышлык эшләдек.* Т.Гыйззәт. *Ак түшле саесканнарны чакырганнар, аларга да зур йомыш тапшырганнар.* А.Алиш

4) Билгеле бер хакимлек, көч карамагына бирү. *Без аларны шушы кәгазьләре, акчалары белән бергә трибуналга тапшырачакбыз.* К.Нәҗми. --- *ул, кайсыдыр гомер юлы чатында адашып, аптырап калган бәндә кебек, бөтен яшәешен язмышы ихтыярына тапшырган да тынып, басылып калган...* Г.Гыйльманов

5) Кемнең дә булса карамагына, җаваплылыгына бирү. *Миңа тапшырылган мәхәлләдә, олуг Җиһангир хәзрәтләре белән мин үтә торган юл өстендә эт үләксәсе ятсын, имеш!* Н.Исәнбәт. *Беренче төркемне сержант Ибраһимовка тапшырдым.* Ә.Айдар

6) Кем дә булса биргән әйберне икенче кешегә, адресатка бирү. *Һич тә көтмәгәндә Һаҗәрнең асравы килә дә, ишан кызы Саҗидәгә тапшырырга дип, алтын йөзек биреп китә.* Г.Ибраһимов. *Ул сезгә шушы конвертны тапшырырга кушты.* М.Кәбиров

7) Мәгълүматны телеграф, радио һ.б.ш. элемтә чаралары ярдәмендә ерак арага җибәрү, билгеле бер дулкыннарда мәгълүмат җиткерү. *Укчы радистлар үзләренең элемтә начальникларыннан бу юлы радиодулкыннарны кайсы дулкында кабул итәргә, позывнойларны тапшырганда, нинди ешлыкка көйләргә икәнлекне борт журналларына теркиләр, пароль атамасын хәтерләрендә калдыралар.* Ф.Хуҗин

8) Радио, телевидение, Интернет аша җибәрелгән хәбәрләр, фильмнар, репортажлар һ.б.ш.ны сөйләү, күрсәтү. *Бакчадагы радио соңгы хәбәрләр тапшырырга тотына.* И.Гази

9) Алла ярдәменә ышанып эш башлау, Аллага тәвәккүл кылу. *Ул арада байбикә: – Тапшырдык булмаса... – диде дә җыена башларга кушты.* М.Хәсәнов. *Әбүзәр, кулларын төкерекләп, картларча: «Тапшырдык алайса!» – диде дә шомарып беткән көрәк сабына ябышты.* А.Тимергалин

10) *иск.* Кияүгә, иргә бирү. *Бәдига: – Әйе, кыз баланы, җиткәч, тапшырган яхшы инде.* М.Фәйзи

**Тапшыра бару** Даими рәвештә, булган берсен тапшыру. *– Әзерләгән икмәкнең һәр потын дивизиянең азыктөлек бүлегенә тапшыра бар! – дип язып җибәргән.* В.Нуруллин. *Авыл мәэмайлары аны, эстафета кебек, бер ихатадан икенчесенә тапшыра бардылар.* А.Тимергалин

**Тапшыра килү** Күптәннән бирле даими тапшыру. --- *Халкыбызның күп гасырлар буена буыннан-буынга әманәт итеп тапшыра килгән рухи байлыгына сәяхәт ясаганчы, аларның – бәһа белмәс хәзинәнең – безнең көннәргә килеп җитүенең катлаулы, аяныч юлларын сурәтли.* М.Хәсәнов

**Тапшыра тору** Даими, эзлекле рәвештә тапшыру. *Шул айда ул әле, Гарин әмерен үтәү йөзеннән, һәр көнне «Анилин Роллинг» директорларына радиодан боерыкларын тапшыра тора.* А.Толстой

**Тапшырып бару** Даими, эзлекле рәвештә тапшыру. *Баксаң, чыннан да, Миңнуллин тапшырасы анализларны ничә көн инде Миңнуллина тапшырып барган икән.* Р.Миңнуллин

**Тапшырып бетерү** Тулысынча тапшыру. *Чөнки ул, планын арттырып үтәр өчен, фуражга тиешле ашлыгын да дәүләткә тапшырып бетергән булып чыкты.* В.Нуруллин. *Имтиханнарны тапшырып бетергәч, алар, группалары белән җыелышып, саубуллашу мәҗлесе үткәрергә булдылар.* Р.Вәлиев

**Тапшырып килү** *к.* **тапшыра килү**. *Бу сыйфатны да алар бер-берләренә буыннан буынга --- түкми-чәчми тапшырып киләләр.* А.Хәсәнов

**Тапшырып кую** Алдан ук, тиз арада тапшыру. *Нигә әле бала язмышын чит кеше кулына уптым илаһи тапшырып куярга?* С.Поварисов

**Тапшырып тору** Даими, әледәнәле тапшыру; хәзер тапшыру. *Вак әйберләрне кулдан-кулга тапшырып тору ансатрак булды.* А.Тимергалин. *Йөгерек дулкыннар, икмәк сыныкларын шунда ук эләктереп алып, малайларның күчтәнәчләрен үрдәкләргә илтеп тапшырып торалар.* А.Хәсәнов

**Тапшырып яту** *сөйл. к.* **тапшырып тору**. *Ай буе фатирда торып, яңа мәктәптә, яңа иптәшләр белән яңа укытучыларга имтихан тапшырып яттылар алар.* А.Гыйләҗев

**ТАПШЫРУ** II *и.* Радио, телевидение, Интернет челтәре аша сөйләнелгән яки күрсәтелгән концерт, лек-

ция һ.б.ш. *Тапшыруның иң соңында бер кыз, Мәскәү эшчеләреннән килгән бүләкләр өчен, үзләренең рәхмәтләрен белдерде.* А.Әхмәт. *Казан тапшырулары тәмамланган чак, карлыкканрак тавышлы колхоз радиоузелы сөйли.* А.Тимергалин

**ТАПЫЛДА́У** *ф.* 1) Тап итү, сугылудан, биеклектән төшеп бәрелүдән каты саңгырау тавыш чыгару

2) Тап-топ атлау. *Табаның тапылдамаса, авызың шапылдамас.* Мәкаль

**Тапылдап алу** Берникадәр яисә бер тапкыр тапылдау

**Тапылдап тору** Озак, даими яки әледән-әле тапылдау; әле, хәзер тапылдау

**Тапылдый башлау** Тапылдарга тотыну

**ТАПЫРДАВЫК** *с.* Сабыры булмаган, түземсез; сикеренә, үрсәләнә торган (кеше тур.). *Тәлгатьнең язгы ташкыннардан соң әле ярларына утырып җитмәгән киң Камага болай да һушы киткән иде, --- бөтенләй тапырдавыкка әйләнде.* Ф.Хөсни

**ТАПЫРДА́У** *ф. к.* **тыпырдау**

**ТАПЫ́Р-ТОПЫР** *иярт.* Тәртипсез, ритмсыз тапырдау авазларын белдерә

**ТАПЫ́Р-ТОПЫР ИТҮ** *ф.* Тапыр-топыр иткән тавыш чыгару. *Тоткын ни барын ачык уйлап җитә алмый, --- күп аяклар тапыр-топыр киләләр дә моның сигезенче камерасының зур йозаклы тимер ишекләрен шалтыр-шолтыр ачып җибәрәләр.* Г.Ибраһимов

**ТАПЫР-ТОПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **тапыр-топыр итү**

**ТАР** *с.* **1.** 1) Иңе зур булмаган, озынча өсйөзле, киң түгел. *Аларның берсендә төрле-төрле калынлыктагы догалык китаплары һәм Коръән ята, икенчесендә төреп куелган тар иңле келәм намазлыклар күренә.* М.Галәү. *Сабырлык ул, балакай, тар сукмак кебек: аның бер ягында бәхет, икенче ягында бәхетсезлек, сагыш...* Г.Гыйльманов

2) Иңе тиешеннән, уртачадан кимрәк, кечерәк булган (әгъзалар тур.). *Кыз аның кысык күзләренә, тар маңгаена карап торды да магнит белән тартылган шикелле артына чигенде ---.* Г.Гобәй. *Рәйхана, иелеп, малайны кочып алды, күңеле нечкәрүдән дымланган күзләрен улыннан яшереп, йөзен аның тар, ябык җилкәсенә терәде.* Р.Габделхакова

3) Сыеп, таман торырга яки җиңел үтәргә тиеш булган предметларны сыйдыруы кыен булган. *Икенчесе зур бер ак сарыкны кечкенә абзарның тар ишегеннән куып кертергә маташа.* Г.Ибраһимов. *Тик уңайсыз шунысы: каймакларын Тар чүлмәккә сала кешеләр.* Һ.Такташ

4) Таман булмаган; кирәкле үлчәмнән кечерәк булган; сыланып торган, иркен түгел (кием-салым тур.). *Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резиналы ботинка иде.* М.Галәү. *Кыска итәкле сары тар күлмәк, биек үкчәле туфли кигән, беләгенә ридикюль аскан Лилия, сәхнәгә чыгып, эскәмиягә утырды ---.* Көмеш кыңгырау

5) Кысан, иркен булмаган, уңайсыз. *Җәнлекләр йортында зур бер аюның кечкенә тар тимер читлек эчендә көнтөн туктамый әйләнеп йөреп торуын күреп, кечкенә чагында Баязит үзе бик гаҗәпләнгән иде.* Г.Ибраһимов. *Без беренче тапкыр 1938 елның көзендә Казан вокзалындагы Столыпин вагонының бер караңгы, тар камерасында очраштык.* И.Салахов

6) Авыр, тоткарлыклы (сулыш, тын тур.). *Уф Алла! дип кем әйтә? Кемдә хәсрәт, шул әйтә. Уф Алла, дип бер суласаң, Тар сулышны киңәйтә.* Җыр

7) *лингв.* Семантикасы конкретрак, абстракт, гомуми мәгънәләрдән кечерәк булган (сүз тур.). *Нәккаш, гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, иң беренче тар мәгънәсе – «ташка уеп бизәк ясаучы, ташка язучы» дигәнне аңлата.* Н.Гамбәр

8) *күч.* Колачсыз, масштабсыз, кечкенә даирәгә хас булган. *Кысык, тар гаилә тормышы эчендә, аннан ярлы үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә каторга келәймәсе суга.* Г.Ибраһимов

9) *күч.* Аерым бер өлкәгә, төркемгә караган; чикләнгән сандагы (кеше тур.). *9250 данә нәшер ителгән журнал тар даирәләргә генә адресланган, аның маңгаена «эштә файдалану өчен» дип мөһер сугылган.* Т.Әйди. *Югары җыелышта инде ничә көн кызу-кызу бәхәсләр бара, һәм, тар белгечләргә хас булганча, капма-каршылыкларның очыкыые күренми ---.* А.Тимергалин

10) *күч.* Берьяклы, чикле, аңлау дәрәҗәсе түбән булган. *Бу тар караш мокытлыкка якын наданлыктан, хөсетлектән килә иде.* Р.Батулла. *Бу – аның тарафыннан тик үзен генә күздә тотып әйтелгән, шуңа күрә тар фикер, дип уйлыйк.* Х.Госман

**2.** *хәб. функ.* 1) Аз, кысан (мөмкинлекләр һ.б. тур.). *Канечкеч өчен киң дөнья булды ләхеттән дә тар!* Г.Камал

2) Аз, җитешмәгән; бик ашыгыч (вакыт тур.). *«Вакыт тар, әйтер сүземне язып хатымда җибәрермен», – ди дә егет, менә атына.* Ф.Кәрим. *Вакыт тар, ашыкмыйча булмый.* Ф.Хуҗин

◊ **Тар җанлы** *к.* **тар күңелле**. *Андый ыгы-зыгының башында торган тар җанлы кешеләрне, җитәкчеләрне дә шул җөмләдән, ялгызларын гына самолёт кабинасына утыртып, зәңгәр күккә очыртып җибәрергә кирәк икән.* Р.Мөхәммәдиев. **Тар җиргә тана башы** *ирон.* Үзләре дә көчкә сыешкан урынга тагын кеше сыйдыру. *Үз абыең өендә яшәсәң дә, тар җиргә тана башы дигәндәй, читен лә кеше өстендә, үзегез беләсез.* А.Гыйләҗев. **Тар күңелле** Көнчел, вак җанлы, башкаларның уңышына ачуы килгән. *Байлар тар күңелле була икән шул...* Ф.Җамалетдинова. *Бу як кешеләре бигрәк тар күңелле, дип китмәсләрме?* Р.Вәлиев. **Тар маңгайлык** Акыллы булмау, алдан күреп, уйлап эш итә белмәү. *Кара гавам арасында әтиләре белән бабаларын такыр кесәлек, тар маңгайлык өчен чүбек чәйнәп искә төшерүче гыйбад табыла ул ---.* В.Имамов. **Тар урын** Нәрсәнең дә булса тиешле таләпләргә җавап бирмәгән, артта калган, кыен хәлгә төшерә торган урыны. *Хәзерге вакытта юллар заманча таләпләргә туры килми һәм икътисадны үстерү, яшәү сыйфатын күтәрүдә тар урын булып тора.* **Тар холыклы** Тиз үпкәләүчән, холыксыз. *Бу сагыну*

*хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан сигез ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», – дип килеп танышкан Искәндәр иде.* Г.Кутуй

**ТА́РА** *ингл. җый. и.* Товарны саклаганда яисә кайда да булса күчергәндә тутыру, урнаштыру өчен кулланыла торган савыт (капчыклар, мичкәләр, тартмалар һ.б.ш.). *Ә Суфия укуын тәмамлагач, тара цехын җитәкли башлады, моңа кадәр анда эшләгән Мөсәлләм Гомәров баш технолог итеп үрләтелде.* З.Мурсиев

**ТАРАЗЫ** *и. гар. иск.* 1) Көянтәле зур үлчәү. *Таразыга җиңел, түләүгә – авыр.* Әйтем

2) Чаян һәм Кыз йолдызлыгы арасында урнашкан йолдызлык атамасы; Үлчәү йолдызлыгы

**ТАРАК** *и.* **1.** 1) Чәч тарау, причёсканы тоту өчен кулланыла торган, тешле-тешле озынча пластинадан гыйбарәт әйбер. *Чөнки Заһидәнең әнкәсе илә танышып йөргәндә, иң кадерле һәм иң кыйбатлы бүләк урынында Хәмит тарафыннан шул тарак бирелгән, ул таракның өстке тирәсе вак кына энҗе илә батырылып, нәкъ уртасында яхшы ук ялтыравыклы бриллиант кисәге дә бар.* Н.Думави

2) Җитен, йон, сүс һ.б.ш. чүбеннән аралау, язу, йомшарту өчен тешле корал. *Якуп абзый – гомер буе өрәңге белән каеннан чәч тарагы, каба, тәрәш тарагы тешәп көн иткән кеше.* Г.Бәширов

3) Махсус үрчетелгән хайваннарның йонын, мамыгын тарап ала торган гади эш коралы. *Кәҗә тарагы*

4) Берәр өслеккә таралган, чәчелгән массаны җыеп алу өчен махсус бармаксыман тешле техник җайланма. *Чәчкеч тарагы*

**2.** *с. мәгъ.* Тешле-тешле. *Тарак мыеклы шыртлавык*

**ТАРАКАН** *и.* Таракансыманнар отрядыннан кайбер төрләре кеше торакларында яши торган канатлы, мыеклы зарарлы бөҗәк. *Тараканнарның ике төре дә продуктларны пычрата, боза ---.* Биология. *Мич башындагы тараканнарның кыштырдауларын тыңлый-тыңлый, Әптерәйнең күз кабаклары авырая башлады.* К.Нәҗми

◊ **Таракан ашаган** Вак-вак тишекләр, таплар белән чуарланган (тире яки күн әйберләр тур.). *Карт ак сакаллы булса да, таза гына тәнле, башында очлы бүрек, өстендә чапан, аягына таракан ашаган читек киеп, читек өстеннән чабата киенгән иде.* З.Һади. **Таракан ашау** Мәгънәсен, кыйммәтен югалту; юкка чыгу, бетү. *Тик минем бәхетемне генә кара таракан ашады, сеңлем.* Н.Гыйматдинова. **Таракан булу** *к.* **ашка таракан булу**. *Таракан булды бит бу кыз минем тормышыма.* Р.Ишморат. **Таракандай таралу** Күпләп үрчү, бөтен җирне басып алу. *Немец халкы – гүзәл халык, тырыш халык, Сокландыра гакыл, зиһен, талантыгыз! Ләкин нигә, илбасарлар, кылыч тагып, Як-якларга таракандай таралдыгыз?* Ш.Мөдәррис. **Таракан катырырлык суык** Торакның, бинаның бик салкын булуы турында. *Күмер белән булган кадәр утын гына түгел, сарай тирәсендәге каерып-куптарып алырдай такталар да ягылып беткән: өйдә таракан катырырлык салкын.* З.Фәйзи. **Таракан качкан** Күптәннән кеше тормаган, ташландык (торак тур.). *Машиналар тукталуга, завод эче таракан качкан өй кебек тын гына булып калды.* Т.Госман. **Таракан керү** 1) Суык үтеп керү, өшетә, тундыра, калтырата башлау. *Менә монда аркага таракан керә башлады.* Г.Бәширов. *Аның инде аякларына да суык – таракан керә башлаган иде.* Ф.Садриев; 2) Шик туып, тынычлык югалу. *Байкучатов, күңеленә таракан кергән хәлдә, госпиталь тарафына атлады һәм монда иптәшләре телгә алган Мартьяновны эзләп тапты.* Т.Әйди. *Әмма аның эченә таракан керде, күңел тынычлыгы югалды.* Ватаным Татарстан. **Таракан салу** Күңелне берәр хәбәр белән шомландыру, борчу, тынычлыкны алу. *[Постоялый дворга], базар бәяләрен сорашкан булып, әллә нинди хәбәрләр белән йөрәккә таракан салучылар кергәли.* К.Нәҗми. **Таракан санап яту** Эшсез яту, берни белән дә шөгыльләнмәү. *Ир кеше таракан санап кына өйдә ята алмый.* А.Гыйләҗев. **Таракан ташлаган** *к.* **таракан качкан**. **Таракан төшү** *к.* **таракан булу**

**ТАРАКА́Н ҖИМЕШЕ** *и. диал.* Киптерелгән сары йөзем. *Иллә мәгәр инде тоз белән таракан җимешен авызга да алырга ярамый.* М.Мәһдиев

**ТАРАКА́НСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Бөҗәкләрнең тараканнарны һәм суфи чикерткәләрне берләштергән өсотряды; *русчасы:* **таракранообразные**. *Таракансыманнар – бик борынгы бөҗәкләр*

**ТАРАКЛАНУ** *ф.* Тарак формасына керү. *Аркылысы-буе бер чакрымнарга сузылган тигез игенлек тәлинкәгә охшап, читен таракланып үскән нарат, чыршылы таулар киртләделәр.* Т.Госман

**ТАРАЛГЫ** *җый. и.* 1) Дирбиядә ике һәм аннан да күбрәк каеш беркетелгән алка

2) Үсемлек сабагында бер урыннан ике яки берничә сабакча, чем, яфрак һ.б. тармакланып киткән урын. *Төп бәбәкнең очында ян ботаклары таралгы (розетка) барлыкка китерә.* Биология. *Мыекчаларын, аннан тамырланган таралгыларны җыеп алу да алдагы ел уңышын күтәрергә булыша.* Бөгелмә авазы

**ТАРАЛГЫСЫЗ** *с.* Таралмый торган. *Таралгысыз томан*

**ТАРАЛДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **таралу**

2) Таралган, таркалган хәлгә китерү. *Таралдырып тарыйсың ла таралган чәчләреңне.* Җыр

**Таралдыра төшү** Тагын берникадәр таралдыру

**Таралдырып җибәрү** Иркенләп таралдыру. *Гәүдәгезне таралдырып җибәрегез.* Р.Рахман

**Таралдырып ташлау** Көтмәгәндә таралдыру

**Таралдырып тору** Даими яки әледән-әле таралдыру; әле, хәзер таралдыру

**ТАРАЛУ** I *ф.* 1) Бер урыннан төрле якка китү. *Биш министр да бүленеп, барысы да начар киемнәр киенеп, үзләре белән унар солдат алып таралдылар, ди, илнең төрле ягына ---.* А.Алиш

2) Бер тирәдән төрле җирләргә күчеп китү. *Авылда чакта төрле җиргә таралып яшәгән семьялар бер тирәгә*

*җыйналдылар.* Ш.Камал. – *Чәчелеп, таралып гомер иткән карындашлар бер килеп очрашыр, табышыр, дип кем әйтә ала?! – дияр идем.* Г.Гыйльманов

3) Төрле җиргә сибелгән булу, теләсә ничек, тәртипсез урнашу, төрле якка чәчелү. *Җәймә өстендә таралып яткан бодайга, җәймә кырыендагы салам өстендә бик әллә ничек итеп кенә җәелеп утырган Әгъләмгә карый-карый --- озын мыегы өстеннән имән бармагын шудырып җибәрде.* Г.Бәширов

4) Бөтенлеген югалту, таркалу. *Шул ел җәй урталарында, каты давыл вакытында, боларның пристаньнары турысында гына бер зур сал тарала.* М.Галәү. *Өйнең инде бүрәнәләренә кадәр череп таралган*

5) Җәелү, киңрәк, зуррак мәйданны биләп алу. *Таралды тирә-якка язгы ташу.* М.Гафури

6) Һавага, фәзага китеп юк булу, очып бетү (тузан, төтен тур.). *Канатланып оча зур эшелон, Күксел төтен кала таралып.* Ф.Кәрим. *Һәм таралды болыт, күк йөзендә, Китек тәңкә булып, Ай калды.* Р.Шәрипов

7) Һавага җәелү (ис, һава тур.). *Өйгә яхшы чәй исе таралды.* А.Шамов. *Бөтен дөньяга сөт исе, сутлы үлән исе тарала.* Ф.Җамалетдинова. *Тәрәзә челтәрләрен тибрәндереп, иртәнге саф һава бүлмәгә таралды ---.* Р.Хәбибуллина

8) Билгеле урынны тутырып яңгырау. *Шуннан соң ук бүлмәгә калтыравыклы моңлы көй таралды.* М.Әмирханов

9) Бөтен тәнне яки аерым әгъзаларны биләп алу. *Самавыр куйсаң, самавырга юшкыны утырмый, җәйге кызуда урак урганда эчеп җибәрсәң, үзенең салкынлыгы бөтен тәнгә тарала ---.* А.Алиш. *Авызга әчкелтем баллы гаҗәеп татлы җиләк тәме таралды.* Ф.Хуҗин

10) Ботаклану, тармаклану. *Тамыр булып тирән җир астына Шахта урамнары тарала.* Һ.Такташ

11) Кешедән кешегә күчеп яки мәгълүмат чаралары ярдәмендә күпләргә барып җиту, ирешү (хәбәр, яңалык һ.б.ш. тур.). *Хәбәр таң атыр-атмас бөтен авылга таралып өлгерде.* Г.Гобәй. *Кырым башкисәрләре турындагы хәбәр сәмум җиле тизлеге белән далага таралды.* М.Әмирханов

12) Күп кешегә күчү, йогу (эпидемия, кизү тур.). *Бермәлне балалар йортында йогышлы тире авыруы – кырчын тарала.* А.Тимергалин. *Башта ящур кырды аларны, ул бәла үткән кебек булган иде, котыру чире таралды.* З.Мурсиев

13) Киң кулланышка керү. *Һәрхәлдә, төгәл мәгънәле терминның таралып, табигыйләшеп китүенә аңа булган ихтыяҗ ярдәм иткән.* А.Тимергалин

14) Яшәүдән туктау (гаилә, оешма, берләшмә тур.). *Таралачак ил ансыз.* Р.Миңнуллин. *Ләкин быел яз колхоз таралды, колхоз белән бергә ферма да таралды.* Г.Гыйльманов

15) *күч.* Бик каты ару, йокы килү, исерү, ис тию сәбәпле тән йомшару, изрәү. *Әпипә, изелеп, таралып, ишегалды уртасында утыра.* Г.Бәширов. *Алар эштән кайтканда, инде радионың кара тәлинкәсе шыгырдап арыган була, бала-чага күптән таралып ятып йокы сутә ---.* А.Тимергалин

16) *күч.* Җан тынычлыгын югалту, рухи төшенкелеккә бирелү. *Яңа гына ишеткән хәбәрдән кинәт таралу*

17) *күч.* Фикер, зиһен, аң томалану, аныклыгы, эзлеклелеге югалу. *Чишмәнең каралган Көмештәй саф суы; Уйлары таралган, йөрәге ярсулы.* М.Җәлил. *Аю бабай инде картайган, зиһене дә таралган.* А.Алиш

18) *күч.* Ниндидер сәбәпләр тәэсирендә төрле хис-кичерешләр юкка чыгу. *Бар хәсрәтем таралады Иркәм килеп кочканда.* Ф.Бурнаш. *Киявемнең Мәскәүдә төпләнеп каласын әйткәч кенә, борчуларым таралды.* М.Әмирханов

◊ **Таралып төшү** 1) Кинәт югалып калу; тотнагын югалту. *Әрнү дә, нәфрәт тә, үкенеч тә, үз хәле белән килешергә теләмәү ачысы да тупланган бу карашлардан Шакир үзен таралып төшкәндәй хис итте.* М.Кәбиров; 2) Вафат булу. *Кузсез, колаксыз калган шушы Миңзифа инәебез кичатна көнне мунча чабынган җирендә ләүкәдә таралган да төшкән, ягъни җаны тәненнән чыгып очкан.* М.Кәрим

**Тарала башлау** Таралырга тотыну. *--- авылда тиф хастасы, зәңгелә авыруы шикелле чирләр тарала башлады, үлүчеләр дә бар.* М.Галәү. *Күзләрне томалап алган томан акрын гына тарала башлады, бераздан ул бөтенләй юкка чыкты да, дөнья кабат үз хәленә кайтты.* М.Кәбиров

**Тарала тору** Акрынлап таралу. *Михаил Топтыгин турындагы күңелле истәлекләр демобилизацияләнгән матрослар белән илнең төрле почмакларына тарала торды.* Н.Әхмәдиев. *Шулай кешеләр тарала торды, Нурия кымшанмады.* К.Кара

**Тарала төшү** Бераз таралу. *Болытлар бераз тарала төшкән.* Г.Әпсәләмов. *Халык тарала төшкәч, безнең янга Әкълимә апа килде һәм, серле елмаеп, ат муенына чүпләмле сөлге бәйләде.* М.Маликова

**Таралып алу** Тиз арада таралу; азга гына таралу. *Шушы хәрәкәт кузгалганнан соң, әдәби җәмәгатьчелектә бер хәбәр таралып алды.* М.Хуҗин. *Аерым кешенең тискәре сыйфаты, йогышлы авыру шикелле, илгә таралып алган чаклар була...* Ш.Галиев

**Таралып бару** Тарала башлау. *Вера кибиткадан килеп чыкканда, балыкчылар, кичке ашны ашап, кайсы кая таралып бара иде.* З.Мурсиев. *Актлар залы таралып бара икән.* Кәеф ничек?

**Таралып бетү** Тәмам таралу. *Апрель числосы керү белән, мәдрәсәдәге бай шәкертләр таралып беттеләр.* М.Гафури. *Җирнең атмосферасы бушлыкка таралып бетәчәк, океан-диңгезләр кайнап, аларның суы пар булып космоска очачак, ә Җир шары, хәзерге Меркурий планетасы шикелле, тереклек итү өчен яраксыз эссе чүлгә әйләнеп калачак.* А.Тимергалин

**Таралып китү** Кисәк таралу. *Монысы өчен мин аеруча сөендем, хәтта Ишембаевның алтын тешен күргәч купкан ачуларым таралып китте.* А.Тимергалин. *Менә тәгәрмәчләре, кыса һәм тарткылары, арата һәм челтәрләре таралып китәр дә, ул җиргә леп итеп утырыр, дип белгәнлегем аркасында, шул тамашаның булуын көтеп карап торганым, узып

*киткәннәрендә озатып калганым бар.* Ф.Яхин

**Таралып кую** Көтмәгәндә таралу. *Әмма бер мәлне шәп гәүдәле бер негр җиңел генә салмак адымнар ясап яныбыздан узды да, «көймәбез» таралып куйды...* Татарстан яшьләре

**Таралып тору** Даими яисә әледәнәле таралу; әле, хәзер таралу; вакытлыча таралу; әлегә таралу. *Хәзергә таралып торыгыз, туганнар.* Н.Фәттах. *Аптыраш: ни сөйләсәң дә, әллә кемнәргә ишетелеп, сүз таралып тора.* Ш.Галиев

**Таралып яту** *сөйл.* Даими таралу; әле, хәзер таралу. *Олы юлга төшкәч, Гайнан тагын бер сөенеп куйды: күңелендә таралып яткан хисләрен, уйфикерләрен тупларга, тәртипкә китерергә җай чыгачак бит...* Г.Гыйльманов

**ТАРАЛУ** II *ф. төш. юн. к.* **тарау** I (*1 мәгъ.*). *Мәһабәт сынлы, алсу чырайлы, матур кеше, куе чал чәчләре артка каратып таралган, кулында чемодан.* Р.Ишморат. *– Каторга хезмәте дә болай булмас, – диде җиткән сакаллы, таралмаган тузган чәчле, чуен төсле кап-кара тәнле, күлмәксез бер ялангачы.* М.Галәү

**Таралып тору** Даими яки әледәнәле таралу; әле, хәзер таралу

**ТАРАЛЫШ** *и.* Таралу күренеше. *Дөрес, бары тик Сиражи мәхдүм генә, уенга катнашы юк кеше шикелле, «Гыйльме хәят вә кәүсәре хас» исеме илә кульязма хәлендә таралыш тапкан бер дәфтәрдән әллә нинди сәер хәлләр табып куанды.* Ф.Яхин

**ТАРАЛЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **таралу** I. *Хәерлегә юрап, кешеләр өйләренә таралышып та өлгермәделәр, ерак-та, Идел өстендә булса кирәк, һава шары күтәрелде...* И.Гази. *Малайлар, Рәүф биргән әмер-күрсәтмәләрне тыңлагач, кайсы кая таралыштылар.* А.Тимергалин

**Таралыша башлау** Таралышырга тотыну. *Бала-чага, юеш үлән арасыннан талаша-талаша җыйган прәннекләр белән авызларын тутырып, учларына чикләвек тотып, таралыша башлады.* М.Галәү. *Подъезд ишегендә ялтыравыклы чәй кәгазенә төрелгән гөл савыты күренү белән, ишегалдында булган кешеләр бер-берләренә карашып алалар, аннары, кем кибеткә, кем үз өенә – кем кая таралыша башлый.* Г.Гыйльманов

**Таралыша төшү** Бераз таралышу. *Бүлмәдәге халык, чак кына таралыша төшеп, аларга юл бирде.* М.Хәсәнов

**Таралышып бетү** Тәмам таралышу. *Шулай кайсы кая китеп, таралышып беттеләр, аннары инде кабат очрашырга да туры килмәде...* М.Галәү. *Кайсы туры юлдан туп-туры өенә, кайсылары, өйгә кайтканчы, кайбер кыйшык тыкрыкларда тукталып үбешәүбешә, ниһаять, яшьләр дә таралышып беттеләр.* Ф.Хөсни

**ТАРАМЫК** *и. бор.* Төп бер нәселдән таралган икенчесе нәсел, зат. *Үзбәк хан гаскәре Азәрбайҗан, Хорасан тарафларына күп мәртәбәләр сәфәр итеп, Һәләкү тарамыклары илә күп маҗаралар улды.* Шура

**ТАРАМЫШ** *и. диал.* Атның ял асты сеңере (элек нечкә бау буларак кулланылган). *Кара атның тарамышы кырык көн чәйнәргә җитә, ди.* Әйтем

**ТАРАН** I *и. гр.* 1) Ныгытма диварын яки капкаларын җимерү өчен, бер ягына тимер очлык кидертелгән бүрәнә; омбы (борынгы сугыш коралы). *Тараннар үз эшләрен итәләр: капкалар чәрдәкләнә, диварлар селкенә.* М.Хәбибуллин. *Агач баскычларны, тараннарны алга чыгарыгыз!* В.Имамов

2) Җир асты тирәнлегеннән су суырта торган җайланма. *Урта Нырты авылында чишмә суын таран белән, ягъни суның төшү авырлыгы белән кудыруны механикалаштыруны сорыйлар сайлаучылар.* Т.Нәҗмиев

3) Сугышта үз корабleңнең, самолётыңның, танкыңның һ.б.ш. техниканың корпусы яки алгы ягы белән дошман транспортын бәреп юк итү алымы. *Миноносец туп-туры көймә өстенә – таранга килә иде.* Г.Әпсәләмов. *Мәскәү янында барган каты сугышларда ук, таран ясап, бер немец самолётын бәреп төшерә [очучы].* С.Поварисов

4) *куч.* Ызгыш-сугышта хәлиткеч адым буларак йөзгә-йөз килү, төртү. *Таранга бара Нурида апа. --- Мәтә Гарәфенә таба томырыла да кукрәгенә ике кулы белән төртеп җиффәрә.* Р.Газиз

**ТАРАН** II *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан чәнечкеле сабаклы, юка яфраклы чүп үләне; *русчасы*: **острица**

**ТАРАН** III *и. зоол.* Карп балыклар семьялыгыннан зур булмаган ярымузгынчы балык; чабакның астөре; Азов чабагы. *Озын җепкә тезгән ак таран, чабак, кызылканатларны да күп алып кайта иде --- [Хәмит].* Ә.Еники

**ТАРАНЛА́У** *ф.* 1) Таран I (*1 мәгъ.*) белән бәреп вату

2) Таран I (*3 мәгъ.*) ясау; бәрдерү, төрттерү. *Сталинград өчен барган каты бәрелешнең берсендә дошман истребителен таранлап бәреп төшергәндә, батыр егет һәлак була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Солтан мәчетенең ишегең таранлаган автобус водителе әйтүе буенча, юлдагы бозлавык аркасында, автобусны контрольдә тота алмаган.* Идел

**ТАРАНТАС** *и.* Утырып йөрү өчен җайланган, артлы, сиртмәле җиңел арба. *Товар белән тулган зур тарантас арба сыгыла-сыгыла килә.* Г.Ибраһимов. *Лапас астында тарантас һәм чөйләргә элеп куйган дирбияләр күренә.* М.Галәү

**ТАРАНТЕ́ЛЛА** *и. ит.* Кызу темплы итальян халык биюе һәм шул бию көе. *Бию сәнгатендә итальян халкының тарантелласы өермә кебек кызу темпта башкарылса, Көнчыгыш халыкларының биюләре, киресенчә, тыйнак, җыйнак булулары белән аерылып тора.* К.Гыйззәтов

2) Шундый характердагы, шундый темптагы музыкаль әсәр

**ТАРА́НТУЛ** *и. ит. зоол.* Бүре үрмәкүчләр семьялыгыннан далаларда, чүлләрдә яши торган агулы үрмәкүч; бөе. *Бигрәк тә тарантул агуыннан исән калу мөмкин түгел диярлек: аңа дәва да, дару да юк.* А.Хәлим

**ТАРАНУ** *ф. кайт. юн.* 1) Үзеңнең чәчеңне тарау, рәтләү, төзәтү. --- *шунда ук өй түрендәге тәрәзәләрнең берсе ачылды, һәм аннан хуҗаның тузгыган башы күренде, ул күршесен таныды булса кирәк, тавыш-тынсыз гына яңадан бүлмә караңгылыгына чумды һәм берничә минуттан киенеп, таранып дигәндәй чыгып та басты.* Р.Мирхәйдәров

2) Үз чәчеңне төрлечә тараган булып кылану, тараштыру. *Шагыйрь чәчләр тарана-тарана керә дә әүвәл тутышлар, аннан соң башкалар белән көрешеп чыга.* Ф.Әмирхан

3) Салам, печән, тирес һ.б. өеме өстендә тибенү (тавыклар тур.). *Бу капка тирәсендә көнозын тавыклар тирес тарана, каз-үрдәк, күркәләр йөри, тизәкләре белән бөтен ишегалдын пычратып, ду килеп бозаулар чабыша.* М.Галәү

**Тарана башлау** Таранырга тотыну

**Таранып алу** Тиз генә тарану. *Аннары ул икенче төрле уйлап бакты. Торыр, юынып-таранып алыр.* Казан утлары

**Таранып кую** Алдан ук тарану

**Таранып тору** Әледән-әле яисә берөзлексез тарану; әле, хәзер тарану

**ТАРАНЧЫ** *и. тар.* Уйгурлар составына кергән субэтнос һәм шул субэтносның бер вәкиле. *«Казакъ кызы», «Таранчы кызы», «Чуваш кызы Әнисә», «Каракалпак кызы» роман-повестьлары дөнья күрү, матбугатта йөзләрчә мәкаләләр бастырылу аркасында, без тугандаш халыкларның байтагын әйбәт кенә танып беләбез.* Т.Әйди

**ТАРАНЬ** *и. төрки к.* **таран** III. *Ярты килограммга кадәр авырлыктагы балыкларны (тарань, алабуга) эчен алмыйча гына тозларга мөмкин.* Йорт эшләре

**ТАРАТА́ЙКА** *и. рус сөйл.* Ике тәгәрмәчле кечерәк арба. *Машиналарга утырып та, атлы таратайкалар белән дә, җәяү дә боларга байтак кеше килде.* С.Лашманчы

**ТАРАТУ** I *ф.* 1) Төркем, җыен, өер һ.б.ш.ны бүлгәләү, төрле якка җибәрү, таралырга мәҗбүр итү; куу. *Һәр төркемне алдан билгеләнгән вагоннарга тараттылар.* Ф.Хуҗин. *Көймәләрне сакларга китерелгән гаскәр башлыклары да, Сөембикәне озата китерүчеләр дә халыкны таратырга кирәклеген әйттеләр.* Р.Батулла

2) Нәрсәләрнең дә булса төрлесен төрле җирдә калдыру, ташлау. *Анакайлар! Ә сез газиз балаларыгызны дөнья буйлап чәчеп, таратып йөрмәгез.* Г.Гыйльманов

3) Төтен, тузан, газ, пар, болыт һ.б.ш.ны һава киңлегенә, фәзага җәелдерү. *Егерме сигезенче июнь, безнең өчен атап диярсең, болытларын таратып, юмарт кояш нурларын сипте.* Ф.Хуҗин. *Фу, Илфир, әллә син инде бөтен җиргә одеколон исе тараткансың.* Р.Сәгъди

4) Бер урында, бер савытта яки бер өем булып яткан нәрсәләрне чәчү, сибү, җәеп салу. *Әүвәлге көннәрдә җыелган юеш күбәләрне дә яңадан таратып киптерделәр һәм шул ук кибәннәр янына китереп аудардылар.* М.Галәү. *Түбән басуга ашлама таратканда, арбадан да җайлы нәрсә юк, бакча эшендә, ферма тирәсендә дә кирәк ул.* А.Тимергалин

5) Төрле җиргә, төрле уңайга сибелдерү, таркалдыру; төрле якка сибү. *Иңбашына ялкындай сибелгән чәчләрен таратып, урман юлыннан бер кыз килә.* Т.Гарипова. *Ай Якты күл аша үзенең нурларын алтын сукмак итеп таратты.* А.Алиш

6) Бүлеп бирү, өләшү. *Галимә өстәлгә тагын бер зур савыт куя, вак тәлинкәләр тарата.* А.Алиш. *Ярдәмче хуҗалык эшчеләренә берәр пот солы таратырга иде исәп.* З.Мурсиев

7) Күп кешегә оешкан рәвештә күпләп бирү, киң массаларга җиткерү (прокламация, листовка, газета, китап һ.б.ш. тур.). *Фәнни китапларны туплап, шәкертләребезгә таратырга кирәк!* М.Акъегетзадә. *Мин ул биргән өндәмәләрнең беразын тараттым инде.* Р.Габделхакова

8) Тәртипсез хәлгә китерү. *Бөтен алачыкны таратып, туздырып ташлады.* Г.Гыйльманов

9) Төрелгәнне сүтү, чишү, ачу. *Ул, баланы таратып, бар җирен карап чыкты: сау-сәламәт бала.* З.Кадыйрова

10) Җәю, киң итеп кую. *Югарыга омтылып түгел, киңәеп, мул ботакларын як-якка таратып, киң «итәкләрен» җиргә кадәр тидереп үскәннәр.* М.Хәсәнов

11) Матди байлыкны (акча һ.б.ш.) туздыру, мал-мөлкәтне өләшү. *Завод милкен арлы-бирле тарату*

12) Эшчәнлектән, гамәлдән чыгару, яшәүдән туктату (гаилә, оешма, берләшмә һ.б. тур.). *Колхозын да, фермасын да таратып өлгергәннәр.* З.Мурсиев. *Ни күрсәк тә, бергә күрербез дип, гаиләмне таратмадым.* Р.Хәбибуллина

13) Йогышлы авыруны күпләп башкаларга йоктыру. *Ул холера авыруын да, крестьяннарга ачу итеп алпавытлар тараткан икән, дип тә сөйлиләр.* М.Гали. *Иген каракларын, мал бурларын алдан сизә, яман чирләр тараткан тычканнарны тота торган мияубикәләр, йортбасар дошманнарны якын җибәрми торган маэмайлар исән.* А.Хәлим

14) *махс.* Тәэсир көчен тагын да киңәйтү (радиация, электромагнит дулкыннар, нурланыш тур.). *Имеш, ул радиация тарата, имеш, әллә нинди авырулар китереп чыгара икән.* А.Гыймадиев. *Алар чагыштырмача көчле, тәртипсез радиодулкыннар таратып, тирә-якларындагы күзәнәкләрнең үзара бәйләнешен өзү сәләтенә ия булалар.* З.Мифтахов

15) Күпләргә илтеп җиткерү, ирештерү (хәбәр, фикер, идея, җыр һ.б.ш. тур.). *Вәли бай һәр җирдә, мин болай, мин тегеләй эшләдем дип, мактанып йөри, фикер тарата.* Г.Нигъмәти. *Авылдашларга уйнап күрсәтеп, бөтен халыкка таратырга иде ак колын көен!* М.Хуҗин

16) *күч.* Төрле авыр хис, кичереш, кайгы-хәсрәт, сагышны юкка чыгару. *Бакча үзенең матурлыгы, шаулап, гөрләп торуы белән минем бу авыр тойгыларымны таратыр төсле иде.* Ф.Әмирхан. *Нәкъ кирәктә, давыл булып килеп, Шикләремне куып тараттың.* Ф.Зыятдинова

17) *күч.* Күпләп җәелдерү, көчен арттырганнан-арттыру. *Менә шушы ике мәзһәб бер диндә халык арасында дошманлык тараткан.* Р.Батулла

**Тарата бару** Бер-бер артлы тарату. *Модельнең башы эченә урнаштырылган беренчел рух аның хисләрен башка рухларга җиткереп, бөтен планетага тарата барды.* З.Мифтахов

**Тарата башлау** Таратырга тотыну. *Әгъдәснең – моңлы баланың – сагышмоңнарын гармун телләре тирә-юньгә тарата башлый.* Р.Кәрами. *Әрҗәле машинага төялеп, яңадан клубка кайтып төшүгә үк, студентларны өйләргә тарата башладылар.* Х.Ширмән

**Тарата тору** Даими тарату; әлегә тарату. *Ә чүп мәсьәләсенә килгәндә, аны кош-корт көн саен тарата торды, шуның нәтиҗәсе буларак, Фәррах белән Хәлимә бер-берсенә яу булып ташландылар.* Ф.Садриев

**Тарата төшү** Бераз тарату. *Мәндәй Ибаны, аксыл чәчле, кызыл йөзле, үшән генә кеше, пыр-пыр очкан чыпчыкларны учын шапылдатып куа-куа йөрде дә сырлы себерке белән җирне арулап, җиргә җәелгән айбагырларны тарата төште.* А.Гыйләҗев

**Таратып алу** Кыска вакыт эчендә тарату. *Азрак кан таратып алдыгыз, җитеп торыр!* В.Нуруллин

**Таратып ату** Тиз генә тарату. *Иске капканы да бүтәннәр кебек сүтеп, таратып атмады.* Р.Газиз

**Таратып бетерү** Бик нык тарату; теләсә кая беткәнче тарату. *Карт һәвәскәр альбомнарын кайсын кая таратып бетергән икән.* А.Тимергалин. *Кулындагы таратып бетермәгән акчаларга карап торды да, икегә бүлеп, яртысын Рәхмәтулла агайга, калганын Гарифулла абыйга бирде.* Ф.Яхин

**Таратып җибәрү** Кинәт тарату; бераз тарату. *Шагыйрь өстәлдәге бер уч акчаны таратып җибәрде, акчаларның берничәсе идәнгә очып төште.* Р.Батулла. *Кыз, --- башын артка чөебрәк чәчләрен таратып җибәргәч, тагы да чибәрләнеп киткән.* З.Мурсиев

**Таратып ташлау** Көтмәгәндә тарату. – *Юк, монда бу кадәр печәнне таратып ташлау ярамас, – диде Минедтин карт.* Ф.Яруллин. *Хәлимә капкадан атлауга, таратып ташланган чүп өемен, юып куелган шампан шешәләрен күргәч, барысын да аңлады.* Ф.Садриев

**Таратып тору** Әледән-әле яисә берөзлексез тарату; әле, хәзер тарату. *Шуларны килгән бер кешегә сүзсез генә таратып тора.* Н.Кәримова

**Таратып чыгу** Барысын да тарату; һәммәсенә тарату. *Шушы өч алманы әтиеңә дә, миңа да, үзеңә дә берәрберәр итеп таратып чык, кәрҗиндә дә берәү калсын!..* Ф.Яхин. *Тирләп-пешеп икешәр рәт чыккач, бераз хәл алдылар да, артларыннан тау кебек өелеп калган тезмәләрне таратып чыктылар.* А.Хәйртдинова

**Таратып яту** *сөйл. к.* **таратып тору**. *Юкса председатель башың белән малайларыңны шәһәргә таратып ятасың дип, авызыңны ачтырмаслар.* Ф.Яруллин. *Нишләп медсанбат марлялар, бинтлар, дарулар таратып ятсын ди инде.* З.Зәйнуллин

**ТАРАТЫП** *рәв.* Һәр ягын ачып, җәеп. *Аннары, җилкәсенә таратып салынган яулыгының почмагы белән күз тирәләрен корытып алганнан соң, ныгый төшкән тавыш белән дәвам итте ---.* М.Хәсәнов. *Ап-ак күлмәк кигән, ак яулыгын таратып бәйләгән, бөрешеп беткән кечкенә карчык усак яфраклары тавышы белән шулай аңа дәшә ---.* Г.Әдһәмова

**ТАРА́У** I *ф.* 1) Чәч, сүс, ял кебек күп җепселләрдән торган нәрсәләрнең бөртекләрен аралап, буйга салу. *Альбомның беренче битләрендә чәчен турыдан ачып тарап үргән авыл кызчыгы күзләрен терәп карап тора.* Г.Әпсәләмов

2) Салам, печән һ.б.ш. җирдә сибелеп яткан нәрсәләрне тырма белән җыю; өемнәрнең өстен тырма, сәнәк белән тырмалау. *Саламны тарап тигезләү*

3) Махсус асралган хайваннарның мамыгын, йонын алу өчен, тарак белән кат-кат йөртү. *Аның әтисе, барлык туган-тумачалары белән, ангор кәҗәләре асрыйлар икән, шуның мамыгын тарыйлар да шәл бәйлиләр, ди.* З.Мурсиев

4) *иск. диал.* Җир өстен тигезләү, тырмалау. *Турысын гына әйткәндә, ил талап авызга кергән хәлвәдән җир тарап авызга кергән икмәк татлырак, дигәннәр борынгылар.* А.Гыйләҗев

**Тарап алу** Тиз генә тарау; бер тапкыр тарау. *Хәзер, Хәмдия җиңгәчәй, чәчемне генә тарап алыйм.* Ә.Еники. *Егет, мыекларын да тарап алгач, башын бераз күтәрә төшеп атлап китте.* Р.Мөхәммәдиев

**Тарап бетерү** Яхшылап, кирәк кадәренчә тарау. *Ул чәчен тарап бетерүгә, барысы да тагын хәрәкәткә килделәр.* Ә.Еники

**Тарап җибәрү** *к.* **тарап кую**. *Чәчне шагыйрьләрчә озын итеп үстереп, артка тарап җибәргән.* В.Нуруллин

**Тарап кую** Алдан ук тарау; тиз генә тарау; гомумән таралган хәлгә китерү. *Әнисе кызына чишенергә булышты, тузгыган чәчләрен тарап куйды, кочагына алып, аның күзге салкыннан алсулана башлаган бит очыннан үбеп алды.* Г.Гыйльманов

**Тарап тору** Даими яки әледән-әле тарау; әле, хәзер тарау. *Үзе бер карыш, сакалы биш карыш, үзе сәкедә ята, сакалының очын киштәгә элгән дә, аны патша кызлары алтын тарак белән тарап торалар, ди.* Әкият. *Бераз хәйран калып, таңга карап тор, Таң җилендә чәчләреңне тарап тор, Таң җилләре моң-зарыңны таратыр...* Р.Вәлиев

**Тарап чыгу** Барысын да тарау, тулысынча тарау. *Миңзай җире бер башыннан икенче башына кадәр бик тигез итеп, пөхтәләп, тарак белән тарап чыкканга охшый иде.* Г.Бәширов

**Тарый башлау** Тарарга тотыну. *Юматша, чишенеп, көзге алдына килде дә күпереп торган куе кара чәчен тарый башлады.* Г.Әпсәләмов

**Тарый тору** Әлегә тарау. *Ай-һай куе булды синең тарагың, Хисләремне кабат-кабат тарадың. Тарый торгач, җанда хис тә калмаган.* Г.Мөхәммәтшин

**Тарый төшү** Тагын да бераз тарау

**ТАРА́У** II *с.* **1.** 1) Бүлгәләнгән; өзек-өзек. *Төн болытлы булса, бу шәүләләр Тагын матур булып яналар, Болытларның тарау толымнарын Алсу ефәк суга маналар...* Ш.Маннур

2) Бергә тупланмаган, сибелгән, чәчелгән хәлдәге. --- *чит-читләре куе камышлык белән уратып алынган зәңгәрсу каралҗым күл буенда яссы түбәле тарау бер авыл барлыкка килде.* Н.Фәттах. *Уйладыңмы халкың язмышларын, җитмеш якта тарау улларын?* Р.Фәйзуллин

3) Бәйләнеше булмаган, бөтенлексез. *«Сак-сок»ның тарау бәетләреннән бу хикәядә нәрсә сөйләнгәнен бер дә хаслы рәвештә белеп булмый.* Г.Тукай

4) *күч.* Буталчык, таркау, бәйләнешсез, төзек булмаган. *Мингаян, үзенең тарау уйларын җыя барып, ничек тә аклану ягын карады.* С.Рафиков

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тәртипсез рәвештә, җыелмыйча, чәчелеп. *Элек тәмле пәрәмәч, төче коймак исе килеп торган чис-*

*та кухнядан борынга ят дару исләре килә, нәрсә-каралар элеккечә үз урыннарында түгел, теләсә ничек тарау яталар ---.* А.Гыйләҗев. *Мандолинда... җанда уйный кыз кулы! Нурланды бүлмәм, яп-якты өстәлем – Моңарчы тарау яткан кәгазь тулы.* Р.Гаташ

2) Аерым-аерым булып, бергә тупланмыйча; бөтенлексез. *Хәтта, беркөнне мәчеткә кергәч, халыкларның тарау утыруларын күреп, бергә җыелышып утырулары хакында тәнбиһ ясаган иде.* Р.Фәхретдин. *Талдым йөзеп. Хәл алыймчы, Комың булып, һәр кузәнәк ятсын тарау.* Л.Зөлкарнәй

**ТАРА́У** III *с.* Тарак белән таралган. *Тарау чәчләр тузып бетте. Матур көннәр узып китте.* Ш.Бабич

**ТАРАУЛЫ** *с.* Таралган. *Тараулы чәч*

**ТАРАУЛЫК** *и.* Тарау (II) булу күренеше. *Вак һөнәрчелек вак патриархаль игенчелек кебек үк искелек, тараулык һәм тарлык белән характерлана.* Тарих

**ТАРАФ** *и. гар.* 1) Як, юнәлеш. *Кеше дулкыны, тоташ ташкын булып, әле бер, әле икенче тарафка агыла.* М.Әмирханов

2) Горизонтның, дөньяның төп яклары. *Көнчыгыш тарафтан ашыкмыйча гына күтәрелеп килгән кояш, нурлары белән офыкны кызыл төскә манып, тиздән көндәлек сәяхәтен башлап җибәрәчәк.* Ф.Хуҗин. *Кояш баешы тарафында авылларны, шәһәрләрне, йортларны, кешеләрне сытып, җимереп, яндырып, җир белән тигезләп, канга сусаган, котырган вәхшиләр кара болыт булып ябырылып, илебез күген каплап киләләр...* Р.Хәбибуллина

3) Тирә-юньнең аерым ягы, бер өлеше. *Ләкин эш хәзрәт уйлаганча чыкмады: хатыннар бер тарафка, ирләр икенче тарафка сафландылар да ике арада юл шикелле бер ачыклык калдырдылар.* Ф.Әмирхан. *Бөтен тараф ак һәм карага әверелеп калган: шәһәрнең биек йортлары да, болытлар да, еракта күренүче агачлык һәм калкулыклар да.* Ф.Яхин. *Авылының газиз һәр тарафы Хәтер сандыгында саклана.* Г.Гайнетдинова

4) Берәр аерым урын. *Кызның өенә һәр тарафтан яучылар килә башладылар.* Г.Тукай

5) Үзара капма-каршы ике ягы булган (эче һәм тышы, алды һәм арты) әйбернең бер ягы. *Ишекнең тышкы тарафында ике хатынның кычкырышкан авазлары ишетелә.* Г.Камал. *Газетаның эч тарафын актара башладым.* Ш.Камал

6) Төбәк, өлкә, як. – *Кырым тарафларында тәрбия алган бәндә ләбаса син, морза, нигә шулай үз кардәшләреңне күрә алмыйсың, – дип, аталык һаман морзаны акылга китерергә чамалый иде.* М.Әмирханов. *Ә көннәрдән бер көнне безнең урамда бер яңалык булды: Гөлсинур апаларга ерак Себер тарафларыннан энесенең улы кайтып төште.* Ф.Җамалетдинова

7) Көрәшүче, көндәш яки берләшеп эшләүче якларның берсе. *Һәр ике тараф, тиешле кануннар үтәлгән хәлдә, үзара ярдәмләшү нигезендә ике дәүләт архивлары арасындагы хезмәттәшлекне киңәйтәчәкләр.* Гасырлар авазы

**ТАРАФДАР** *и. фар.* Нинди дә булса идеяне, фикерне яклаучы, билгеле бер иҗтимагый группага теләктәшлек итүче кеше. *Юк, Әлтафи – реализм тарафдары.* М.Мәһдиев. *Бу мәсьәләдә мин сезнең иң якын тарафдарыгыз, галиҗәнаплары.* М.Хәбибуллин

**ТАРАФДАРЛЫК** *и.* Кемнең яки нәрсәнең тарафдары булу хәле. *Дөрес, иҗатчыга ниндидер тарафдарлык ярлыгы тагу – четерекле нәрсә.* Р.Фәйзуллин

**ТАРАФДАРЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Берәр фикерне, идеяне яклау, берәр төркемгә, кешегә теләктәшлек итү. *Залим һәм хаиннәргә тарафдарлык итү, оятсыз һәм гыйффәтсез кешеләрнең батырчылыкларына сәбәп булу, бозыклыклары сәбәпле фасикъларны мактау кебек эшләрнең һәрберсе башкаларның дөньяларын төзәтү өчен үз ахирәтен харап итү була.* Р.Фәхретдин

**ТАРАФДАРЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **тарафдарлык итү**. *Ләкин безнең Камил бай --- андый-мондый тарафдарлык кылу тиеш түгел, дип сөйләгән нотыгыбыздан риза булмаган булса кирәк.* Г.Баруди

**ТАРАФДАРЧЫ** *и. ялг. к.* **тарафдар**. *Һәр партия үз программын мактап, фикерен тугры дип, үзенә тарафдарчылар күбәйтергә иҗтиһат кыла иде.* Ш.Мөхәммәдев

**ТАРАФЛЫ** *с.* Билгеле бер караш, фикер яки кеше яклы булган. --- *Инде кадим тарафлы имам сайларга кирәк икән.* Г.Баруди

**ТАРАФСЫЗ** *с.* **1.** Бер тарафка да иярмәгән, бер тарафны да якламаган, нейтраль, битараф. --- *Мәгълүмат чарасының кем акчасына яшәве мөһим түгел, ул тарафсыз, чын хакыйкатьне яктыртырга тиеш.* Безнең гәҗит

**2.** *рәв. мәгъ.* Бер тарафны да өстен куймыйча, объектив. *Мисалга, В.Дробков --- аларның дәгъвалары табигый икәнлекне дә тарафсыз (объектив) күрсәтүне хаҗәт санамаган, Афина һәм Мәскәү файдасына хезмәт итәргә тырышу аны хакыйкатьне ачудан тәмам ераклаштырган иде.* Т.Әйди

**ТАРАФСЫЗЛЫК** *и.* Бер тарафта да булмау позициясе, нейтральлек; объективлык. *Әгәр журналист --- кучтәнәчләр төяп кайтса, акча алса (андый мисаллар буа буарлык), нинди тарафсызлык, гаделлек турында сүз барырга мөмкин?!* Безнең гәҗит

**ТАРАФТАН** *бәйл. к.* **тарафыннан** *Мондый хыянәтне сезнең тарафтан гомердә көтмәгән идем.* А.Хәсәнов. *Барып сугышып карагыз, ә без үзебезнең тарафтан сезне якларга тырышырбыз.* А.Вергазов

**ТАРАФЧЫ** *и. к.* **тарафдар**

**ТАРАФЫННАН** *бәйл.* «Хәрәкәт чыганагы, тәэсир итүче, активлык күрсәтүче яктан» мәгънәсендә. *Ләйлә татар шагыйрьләреннән берсенең «Сагыну» исемле шигырен җырлый, Нәфисә дә татар композиторы тарафыннан «Сагыну»га билгеләп ясалган көйне уйный иде.* Ф.Әмирхан. *Бергә яшик, балалар, оныклар үстерик, бер-беребезнең кадерен белеп, Ходай тарафыннан бирелгән гомерләребезнең ямен күреп яшик...* Г.Гыйльманов

**ТАРАШ** *и.* Чәчне билгеле бер рәвештә тарау һәм шулай таралган чәч. *Кыйгач аның кашлары. Матур чәч тарашлары.* М.Җәлил

**ТАРАЮ** *ф.* 1) Тар хәлгә килү, тар булу. *Аннары шикәр чире белән*

*авыручыларның аяк кан тамырлары тарая.* Кызыл таң

2) Кысынкылану; урын, мәйдан кечерәю. *Ләкин алай итү үзе күптөрле кыенлыклар тудырды: эшчеләргә иркенләп эшләр өчен урын тарайды...* М.Хәсәнов. *Язлыкта елга ярларыннан чыга, таша, дулый, котырына, ә җәен, корылыкта, киресенчә, тарая, саега, кибә.* Р.Кәрами

3) *лингв.* Берничә мәгънәнең кайсыларыдыр, аңлашылмый башлау сәбәпле, кулланыштан төшеп калу. *Татарча дини текстларда (мәсәлән, «Коръән тәфсире»ндә) «җәза» сүзен «воздаяние» мәгънәсендә куллану күзәтелсә дә, «җәза»ның бүгенге мәгънәсе тарайган, ул «яман эш өчен түләтү»гәрәк тарта.* А.Тимергалин

4) *күч.* Кем өчен дә булса шартлар начарлану; мөмкинлекләр чикләнү; билгеле бер кысаларга кертелү, кысылу. *Димәк, каты куллы баярларның азатлыгы тараячак.* Р.Батулла

5) *күч.* Сүлпәнләнү, акрынаю, берникадәр кыенлашу, авыраю (сулау, фикер йөртү тур.). *Шул сәбәпле һәммә тәмәке тартучылар авыр тәнәффүс кылалар, сулуы тараядыр, йөткерәдер.* К.Насыйри. *Яше кипте [аның], зиһене тарайды, күңеле хәтер вә тәкъвалыкка чорналды.* М.Әмирханов

6) *күч.* Кимсенү, җәберсенү, ачулану, үчегү (күңел, хис һ.б. тур.). *Кеше күңеле шундый инде ул, кайвакытта тараерга да мөмкин анысы.* Ф.Яхин

7) *күч.* Куллану өлкәсе, эчтәлеге чикләнү. *Инде сөйләшүнең темасы һаман тарая, конкретлаша иде.* М.Юныс. *Сүзләрнең кулланылыш даирәсе тарая икән, димәк, сөйләмдә файдаланылган сүзләр дә кими.* Казан утлары

**Тараеп алу** Беразга гына тараю. *Бу урында бераз тараеп ала да олы, киң бүлмәгә килеп чыга...* Г.Гыйльманов

**Тараеп бару** Торган саен, акрынлап тараю. *Минем вакыт тараеп бара иде инде.* Ф.Яхин. *Бүген телебезне белү бик сирәк урыннарда таләп ителә, ягъни аның куллану сферасы элек тә тар булса, хәзер ул бөтенләй тараеп бара.* Безнең юл

**Тараеп бетү** Тәмам, бик нык тараю. *Үлән кыягының очы нигә тараеп бетүен өйрәнә бугай ул.* М.Хуҗин

**Тараеп килү** Соңгы арада акрынлап тарая башлау. *Моның өчен мөһим булган ирекле матбугат, ирекле фикер алышу өчен шартлар да торган саен тараеп килә.* Безнең гәҗит

**Тараеп китү** Кисәк тараю. *Җавап сүзе сорады һәм, күңеле тараеп китеп, премиянең кечкенәлегенә канәгатьсезлеген белдерде [ул].* Ф.Яхин

**Тараеп кую** Кинәт тараю; тарайган хәлгә килү. *Юл-сукмак тар, бара-бара ул бөтенләй тараеп куя ---.* А.Гыйләҗев. *Түләк Ябалак тавының иң биек кыясыннан кош кебек очып төшкәндә, Сайдәнең йөрәге кысылып, сулышы тараеп куя иде ---.* Г.Гыйльманов

**Тараеп тору** Даими яки әледән-әле тараю; әле, хәзер тараю; тар булып күренү. *Сүбәдәйнең йөзе озынча, өскә таба маңгае тараеп тора, киң кашлы, юка иренле.* М.Хәбибуллин

**Тарая башлау** Тараерга тотыну; тараю билгеләре бераз сизелү. *Үй үзенә эшли башларга вакыт икәнен сизенә, ләкин кайдан тотынырга кирәк икәнен белми дә каушап кала иде: бүлмә тарая башлады, тарая, тарая... мевнә инде ул Хәятны кысарга ук тотынды...* Ф.Әмирхан. *Кесәләре калыная барган саен, кайберәүләргә җир тарая башлыймы соң әллә...* Р.Мөхәммәдиев

**Тарая бару** Торган саен күбрәк тараю. *Ат көннән-көн азрак тирли, үргә җиңелрәк менә, танау тишекләре тарая бара, күзендә дә шашкынлык кими, корсагы күзгә күренеп кими иде.* Р.Батулла

**Тарая төшү** Бераз тараю; тагын да тараю. *Көннәр узу белән, алачык миңа тарая төшкән кебек булды.* Н.Хәсәнов. *Анда инеш тарая төшә, улактан аккан чишмә кебек, кысынкы арадан, сикерә-сикерә, ары чабып китә һәм шушы бусаганы үткәннән соң, кабат киңәя төшеп тынып кала иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТАРБАЛАК** *и. иск. кимс.* 1) 1917 елга кадәрге чорда европача киенгән татар яшьләренә кадимчеләр биргән кушамат. *Өченче көн шул динсез җәмгыятькә кергән, анда теге тарбалаклар, әдәбият кичәсе ясыйбыз, файдасын җәмгыятькә бирәбез, дип, прашиния биргәннәр икән, бу динсез шунда яшьләрне яклап утырган була, ди.* Г.Камал

2) Стиляга. – *Әмонысы, әрәмтамак, тарбалак булганың өчен!.. – дип, җан ачуым белән, кулларым ут булып янганчы, уңлы-суллы яңакладым тегене.* М.Хәсәнов

**ТАРБАНУ** *ф.* Алгы аяклары белән һаваны тырнагандай итү (ат тур.). *Толпар тарбануыннан, шоңкар талпынуыннан беленә.* Мәкаль

**ТАРГЫЛ** *с.* Кара кызыл; каралы-кызыллы. *Сыер алсаң, танып ал, танымасаң, таргылын ал.* Мәкаль

**ТАРГЫЛТАШ** *и.* Гранит. *Тауда булыр таргылташ, Тарыкса, күздән чыгар яшь, Тар култыктан ук тисә, Тартып алыр карындаш.* Дастан

**ТАРИКАТЬ** *и. гар.* 1) *иск.* Юл, мәсләк

2) Аллаһка ирешү максаты белән тотылган юл; берәр мөридкә, ишанга ияреп, билгеле шартларны кабул итеп, әхлакны яхшыртуны, начар гадәтләрдән арынуны, тәүхиднең хакыйкатенә ирешүне максат иткән тәсаувыф юлы. *Сәет әфәнде нәкышьбәндия һәм шәзилия тарикатенең (суфилар тоткан дини юнәлеш) билгеле суфи шәехе иде.* Кызыл таң

3) Берәр шәхескә ияргән кешеләр өчен билгеләнгән әхлакый һәм социаль кагыйдәләрнең бөтенесе һәм шул кагыйдәләргә корылган җәмгыять. *Соңгы гасырларда Бохарада --- тарикатькә даир нәрсәләр тәрҗемә ителеп вөҗүдкә килгәннәр.* Ф.Әмирхан. *Тарихка, рухи мираска кагылышлы сәхифәләрдән Казанның борынгы зиратлары, ислам тарихы, Идел буендагы тарикатьләр турындагы һәм башка кызыклы темаларны колачлаган язмаларны укырга мөмкин.* Казан утлары

4) Аллаһка ирешү юлындагы дүрт дәрәҗәдән (шәригать, тарикать, мәгърифәт, хакыйкать) икенчесе; тәсаувыф, суфичылык. *Ул кырык мәкамнең ун мәкаме шәригатьтә торыр, вә ун мәкаме тарикатьтә торыр, вә ун мәкаме мәгърифәттә торыр, вә ун мәкаме хакыйкатьтә торыр.* Ә.Ясәви

**ТАРИКАТЬЧЕ** *и.* Тарикатьләр тарафдары булган, нинди дә булса тарикать юлын тапкан кеше

**ТАРИКАТЬЧЕЛЕК** *и.* Тарикатьче булу

**ТАРИФ** *и. гар.* Законлы түләү нормасы (мәс., эш хакы, товар яки билет хакы, салым һ.б.). *Безнең эшләү – эш башыннан, аннан соң шуңар өстәмә рәвештә шул артык ике сәгать өчен тариф ставкасын да китереп кушачаклар.* А.Алиш. *Моңа кадәр сәламәтлек саклау оешмасында эшләүче медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә акча бердәм тариф челтәре буенча түләнә иде.* Ватаным Татарстан

**ТАРИФИКА́ЦИЯ** *и. рус* Тарифларны билгеләү ысуллары, кагыйдәләре, системасы. *Укытучы хезмәтен стандартлаштыру илдә мәгариф системасын камилләштерү белән бәйләнешле күптөрле мәсьәләләрне хәл итәргә, шулай ук аттестация, тарификация --- укытучының квалификациясен билгеләргә ярдәм итә.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Мобиль телефон аша түләсәң, парковканың минималь вакыты – 30 минут, аннары 15 минут саен тарификация.* Безнең гәҗит

**ТАРИФИКАЦИЯЛӘ́Ү** *ф.* Тарификация ясау, тарификация үткәрү. --- *«Мөхәммәдия» һәм «Галия»не тәмамлаган укытучыларның белемен тарификацияләгәндә, аларны Учительский институт тәмамлаганнар белән тигез бәяләргә, дигән күрсәтмә булган.* М.Мәһдиев

**ТАРИФЛЫ** *с.* Билгеле бер тарифка көйләнгән, билгеле бер тариф буенча башкарыла, түләнә торган. *Махсус тарифлы билетлар сату бүген башланды.* Казан утлары. *Исәпләүләрнең бер тарифлы системасына күчү өчен, гариза язарга кирәк.* Шәһри Чаллы

**ТАРИФСЫЗ** *с.* Тариф куелмаган, тариф белән билгеләнмәгән

**ТАРИХ** *и. гар.* 1) Чынбарлыктагы берәр аерым күренешнең башыннан ахырынача, бөтен яшәү дәверендә булган вакыйгалар, үзгәрешләр тезмәсе. *Тарих шул майлаган арба кебек шома гына бармый.* Г.Исхакый. *Кешелекнең бөек тарихы, Газинур, азатлык өчен көрәш тарихы ул.* Г.Әпсәләмов

2) Җәмгыять үсешенең билгеле бер чорында булган вакыйгалар тезмәсе. *Татар халкының Урта гасырлар тарихы битләреннән гаделсезгә төшереп калдырылган, әмма бик игътибарга лаек олуг тарихы бар.* Р.Фәхретдинов

3) Берәр ил, объект һ.б.ш.ның барлыкка килүеннән башлап саналган вакыйгалар тезмәсе. *Институт тарихында Ильясова яшендәге хатынкызның мондый урынга сайланганы юк иде әле.* М.Маликова. *Букинистлар белән сөйләшенеп, татар тарихына караган искерәк китапларны минем өчен калдырып торырга, дигән килешүебез бар иде.* А.Тимергалин

4) Үсештәге тормыш, чынбарлык. *Тарих юлы тулы хата, хата... Тарих юлы – безнең үткәннәр. «Иң дөрес юлдан барасыз!» – дип, Хата юлдан алып киткәннәр дә Үзләре дә... үлеп беткәннәр...* С.Рәхмәтулла

5) Үткән-булган вакыйгалар, кешеләр, күренекле шәхесләр һ.б. турында белешмәләр, истәлекләр. *Җырлап туктагач, бер-ике сүз белән җырның тарихы турында белешмә бирде: монысын фәлән авылның фәлән кешесе чыгарган, диде ---.* Н.Фәттах

6) Кешелек җәмгыятенең барлыкка килүе, үсеше турындагы фән. *Баксам, ул чыннан да әллә кем булмаган икән: сәясәт белән тарих фәнен бутап, хакыйкатьне идеология белән бозып харап иткән галим кисәкчеге.* Ф.Яхин

7) Аерым фәннәрнең үсешен өйрәнә торган тармак. *Сергей Королёв белән Вернер фон Браун – ракета техникасы тарихында бердәй бөек фигуралар.* А.Тимергалин. *Менә мин үзем КПСС тарихы буенча яклаган идем диссертацияне.* Н.Кәримова

8) Җәмгыять үсеше турындагы дәрес предметы. *Ул аларны тарихтан укытты.* Ф.Яхин. *Математика, әдәбият, физика, химия, тарих фәннәре буенча барлык класслар өчен дәреслекләр җыйды, шуларны укырга утырды.* З.Мурсиев

9) Җәмгыять үсеше турында язылган китап, дәреслек. *Исемең калсын үзең үлсәң дә, Тарихларда укып ятларлык.* М.Җәлил

10) Башы-азагы, үсеше булган вакыйга, маҗара. *Клиникадан чыгып киткәнче, Җәмилә Закировна аның бүлмәсенә сугылды. Дәүләтшин өстәл артында авыру тарихы тутырып утыра иде, профессор кергәч, аягүрә басып, халатын тарткалады.* М.Маликова. *Сүзен нидән башларга микән дигән шикелле, Мәхмүт тамагын кыргалап торды да үзенең мәхәббәт тарихын сөйләп китте ---.* Ф.Хуҗин

11) Аерым сөйләнерлек яисә сөйләнеп йөртелә торган вакыйга; хикәя, маҗара, кыйсса. *Сарсымбайда үткәргән төндә сүзнең күбе шул турыда булды. Симез найманнарның яман кара тарихларын, үзе алар белән ничек көрәшкәнен озак-озак хикәя кылды.* Г.Ибраһимов. *Бөтен күңелемне ниндидер серле, могҗизалы тарих тыңларга көйләдем.* Г.Гыйльманов

12) *иск.* Дата. *Тарих мең дә тугыз йөз дә Туксан алтынчы ел эчендә, Рәстәмне үтерәләр Унтугызынчы апрель кичендә.* Бәет. *Тарих мең дә тугыз йөз дә... ярар инде, Сюжетыбыз безнең чорга карар инде. Оста кеше дөнья малын табар инде, Культуралы ысуллары булгач имди.* Г.Афзал

◊ **Тарих арбасы** Кешелек җәмгыятенең туктаусыз үсештә, хәрәкәттә булуы турында. *Әллә вак-төяк бәхәсләр, ызгыш-талашлар эченә чумып, тарих арбасыннан төшеп калырбызмы?* Р.Вәлиев. *Сабырлык – киңәшче генә, тарих арбасы тизлеген арттырган вакытта һич тә соңарырга ярамый, кадакны вакытында сугып барырга кирәк.* Ф.Яхин. **Тарих бите** Тормыш-яшәеш барышында булган вакыйгаларның халык хәтерендә саклануы. *Карасак та тарих битен актарып, Ышанырбыз: батыр, сугышчан халык! Мәгърифәтле дигән олы аты бар...* И.Юзеев. *Телен югалткан халык иртәгә тарих битеннән төшеп кала.* Мәдәни җомга. **Тарих битенә уеп калдыру** Мәңгеләштерү, киләчәк буыннарга калдыру. *Ул әнә, авыр хәсрәт килгән саен, үзенең үткен балтасы белән ишегалдындагы карт шомырт агачына*

*кирт ясый, әйтерсең күңелдәге ярасын, киләчәк буыннар күрсен өчен, тарих битенә уеп калдыра*. Ф.Яруллин. **Тарих битенә элә**г**ү** Берәр әһәмиятле гамәле белән танылу; мәңгеләшү. *Талантлы рәссамның матур рамга киергән киндеренә эләгү – ул бит чал тарих битенә эләгү, мәңгелеккә атлау!* А.Хәсәнов. **Тарихка керү** Танылу; мәңгеләштерелү. *Әгәр бу тарихи, затлы китап булса, без синең белән, Азат дус, тарихка керәбез.* А.Гадел. **Тарихка язып кую** *к.* **тарих битенә уеп калдыру**. *– Без синең исемне Волконскаялар, Трубецкаялар белән рәттән тарихка язып куярбыз, – диде Әнвәр.* М.Маликова. **Тарихта калу** 1) Танылу, хәтердә саклану, мәңгеләштерелү. *Әхмәтҗан Нуриман исемле бер мулла белән Зәки остазның бәхәсе тарихта калган.* Р.Батулла; 2) Кулланыштан төшеп калу, актуальлеген югалту. *Политинформация заманнары инде тарихта калды*. З.Мәхмүди. **Тарих тәгәрмәче** Иҗтимагый үсешнең котылгысыз хәрәкәте, барышы турында. *Бу көн тарих тәгәрмәчендәге бер мең бер йөз илле бишенче ел әйләнәсе иде.* В.Имамов. *Тәк, тудым да һава суладым. Тарих тәгәрмәче әйләнгәндә, Туктасын дип, таяк тыкмадым.* Г.Афзал. **Тарих чүплеге** Тарихка яманаты чыккан кешеләр, вакыйгалар турында. *Илнең, халкыбызның тарих чүплегенә барып ерәлгәнен кул кушырып көтеп утыру ярамас*. Р.Мөхәммәдиев. *Синең кебекләрне без тарих чүплегенә төртеп төшерергә, шунда олактырырга тиешбез!* Ф.Яхин

**ТАРИХИ** *с. гар.* 1) Тарихта булган, тарих дәвамында булып үткән. *Шулай ук Нугай урдасының бу картада урын алмавы – аның тарихи роле төшә бару сәбәбеннән дип аңларга кирәк ---*. Шура. *Шәрык вә Гаребне бергә тоташтыручы Идел елгасы өчен көрәш – гасырлар буенча килгән тарихи бер вакыйгадыр.* Г.Гобәйдуллин

2) Тарихка бәйле, тарих закончалыкларыннан килеп чыккан. *Шулай да тарихи процессларның бер кануны бәхәссез: тарих мизанында әле золым ягы баса, әле демократия җиңеп чыга.* А.Тимергалин. *Тарихи үсеш дәверендә вакыт-вакыт булып торган мондый хәлләр кешеләрнең тормышында да урын алалар.* Ф.Яхин

3) Тарихта зур һәм киң колачлы булуы белән аерылып торган. *Бу тарихи вакыйгалар Приск Панийский язмаларында сакланган.* З.Хәким

4) Билгеле бер өлкәдә әһәмиятле, бик зур казаныш саналырлык. *СССР төзелү – дөньякүләм тарихи вакыйга, шуңа да бу көннәрдә коммунистларның бер платформада, катгый бер фикердә торуы зарур.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә бүгенгесе – 1943 елның 5 август көнендәгесе – Кызыл китапка язылып кала торган тарихи җиңү.* С.Поварисов

5) Әһәмиятле берәр вакыйга, бөек кешеләр исеме белән бәйләнгән; борынгы чорларда төзелгән. *Безне еш кына Ленинградка увольнениегә җибәрәләр, ял көннәрендә төрле тарихи урыннарга экскурсияләргә, театрларга алып баралар иде.* В.Нуруллин. *Баксаң, тарихи йорт инде үзе.* А.Тимергалин

6) Тарихта булган; чын, дөрес. *Нинди генә тарихи фактны алсагыз да, аны шушы күзлектән карарга тырышыгыз, дигән сүзләр генә истә калган.* Р.Вәлиев. *Әлегә безне тарихи татар-монголлар белән бутау дәвам итә ---*. Т.Әйди

7) Тарих фәнендә өйрәнелгән, тарих фәне белән бәйләнешле. *Байтак тарихи документлар экспонатлар итеп тә куелган.* В.Имамов. *Аттила белән Баладайның тарихи елъязмаларда беренче тапкыр телгә алынулары Көнчыгыш Рим империясе идарәчесе белән Маргус шәһәрендә (Позаревак) төзелгән килешүләргә бәйле.* З.Хәким

8) Үткәндәге истәлекле зур вакыйганы сурәтләгән, шуңа багышланган (әдәбият, сәнгать әсәрләре тур.). *Тарихи романнарыгыз укырга яраксыз.* А.Тимергалин

9) Ерак үткәннәргә бәйләнешле. *Бүгенге көндә аларның барысы да тарихи истәлек кенә булып калды.* М.Юныс

10) Элек халык тормышында зур роль уйнаган; югалмас эз калдырган. *Мәгъдәни кулъязмасындагы тарихи эзлеклелеккә, борынгы Болгар дәүләте чорыннан алып XX гасыр башына кадәр яшәгән һәм эшләгән күренекле тарихи шәхесләр турында кыйммәтле мәгълүматлар туплый алуына соклануыннан хәйраннар булды.* М.Хәсәнов

11) Борынгы, ата-бабалардан килгән. *Алар үз тарихи тамырларын, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын кадерләп саклый.* Т.Нәҗмиев. *Хәзер инде без тарихи Ватаныбызга кайтырга һәм аңа милли дәүләт буларак ныгырга булышырга тиеш.* А.Нәҗми

12) Төрле чорларга караган фактларны чагыштырып, теге яки бу өлкәнең эволюциясен өйрәнә торган (фән тармаклары тур.) *Тарихи грамматикада шулай ук күп кенә кушымчаларның статусы үзгәрү күренеше, ягъни сүзьясагыч морфемаларның формаясагычларга күчүе, һәм киресенчә, күп кенә формаясагыч кушымчаларның сүзнең тарихи тамыры белән берегүе яки сүзьясагычларга әверелүе дә билгеләнгән.* Ф.Хисамова

13) Электән килгән, буыннан-буынга тапшырыла торган. *Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?* Г.Тукай

**ТАРИХИЛЫК** *и.* Тарихи фактларга нигезләнгән булу үзлеге; тарихи чынбарлыкка туры килү күренеше. *Зиратларның иң характерлы, тарихилык ягыннан иң кыйммәтле истәлекләре, әлбәттә, язулы кабер ташлары*. М.Госманов. *Кушлавыч егетенең милли фикерләвенә офыклар киңлеге, тарихилык хас*. Х.Миңнегулов

**ТАРИХКА́ЧА** *с.* 1) Кешелекнең иң борынгы чорына караган. *Аны [бодайны] 10 мең ел элек, тарихкача чорда игә башлаган булулары ихтимал.* Биология

2) Борынгы язма һ.б. ядкәрләрдә әле теркәлмәгән чордагы. *Садри Максуди язганча, төрки телнең гомуми байлыгы төркиләрнең инде тарихкача заманнарда ук мәдәният үсешендә шактый югары дәрәҗәгә ирешүен күрсәтә.* Р.Хәкимов

**ТАРИХЛЫ** *с.* 1) Тарихы булган; борынгы. *Без – мәдәниятле, тарихлы һәм мираслы халык.* Н.Исәнбәт. *Әлбәттә, тарихлы борынгы халыкның үзенең үткәнә гәүдәләнгән мифологиясе дә булырга тиеш.* И.Хуҗин

2) *иск.* Датасы куелган, датасы күрсәтелгән. *«Нижний өлкәсе Намика авылы Котлыгмөхәммәд мирза бине Ягъкуб» дип язылган 1200 нче (1785) тарихлы кәгазьне үз күзебез белән күрдек.* Ш.Мәрҗани

**ТАРИХЧЫ** *и.* 1) Тарих фәннәре галиме, тарих белгече. *Гуннар арасындагы бериш халыкларның утрак тормыш белән көн күргәннәрен шул чорның күп кенә тарихчылары Биармия дип атыйлар.* М.Хәбибуллин. *Тарихчылар папирус төргәкләренә уелып язылган меңләгән китап хакында сүз йөртәләр бит.* М.Әмирханов

2) Берәр фәннең барлыкка килүен, үсешен өйрәнүче галим. *Әдәбият тарихчысы профессор Хатип әфәнде Миңнегуловның «Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты» дигән хезмәте аерым китап буларак 1976 нчы елда дөнья күргән иде.* Ф.Яхин

3) Тарих укытучысы. *Тарихчы шатлана, чөнки укучының сорау бирүе, гомумән, синең фәнең белән кызыксыналар дигән сүз, ул җанланып сөйли башлый.* М.Мәһдиев

**ТАРКАЛУ** *ф.* 1) Аерым өлешләрдән, элементлардан торган нәрсәләрнең бөтенлеге, төзеклеге бозылу, төзелеш тәртибе югалу. *Аннан соң ул Мәргәннең тузып таркалырга җиткән аяк киемен салдырды, ярага әлеге яфракларны япты һәм, букча кебек нәрсәсеннән чүпрәк кисәге алып, ярасын бәйләп куйды.* И.Хуҗин

2) Тәртипсез рәвештә төрле якка таралу (җан ияләре тур.); таралышу. *Шуннан соң бандитлар таркала һәм кайсы кая кача башладылар.* Ш.Камал. *Чәчелеп, таркалып йөрмәгез әле, бар хәсрәтегез көмеш булсын.* Т.Әйди

3) Тәртипсез хәлгә килү, тузып, таралып яту. *Юлбасарларга килсәк, алар берничә көннән соң тагын тау куышына килделәр һәм дошманнарының гәүдәсе югалганлыгын, ә акча капчыкларының җирдә таркалып ятканын күрделәр.* Әкият

4) Гадирәк, ваграк төзелешле кисәкләргә аерылу (химик матдәләр, кушылмалар һ.б. тур.). *Өстән төшеп торган сары яфраклар, шәһәр утларына бәрелеп, миллионлаган тәңкәләргә таркала сыман.* Э.Гадел. *Чөнки бу вакыт эчендә тере организмнар гына түгел, теләсә нинди ныклы материалдан ясалган корабльләр дә атомнарга таркалачак.* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Берәр иҗтимагый оешма, төркем, берләшмә һ.б.ш.ның әгъзалары арасында бәйләнеш өзелү, бердәмлек югалу. *Шушы хәлне аңласаң, соңгы елларда кеше үтерү, йорт басу, гаилә таркалу статистикасының кинәт үсеп китүенә төшенү бер дә катлаулы эш түгел.* М.Юныс. *Шулай нигезләр таркала, милләтебез сыеклана.* Ф.Яруллин

6) *күч.* Нинди дә булса тарихи-традицион иҗтимагый күренеш яки иҗтимагый строй яшәүдән туктау, юкка чыгу. *Без изге һәм какшамас дип санаган Ватан таркалды.* Ф.Яруллин. *Илләр таркалалар, президентлары алышына, ул империяләрнең исемнәре дә үзгәрә.* Ф.Яхин

7) *күч.* Барып чыкмау, тәртибе бозылу, мәгънәсе югалу, өзелү, сүтелү (план, эш һ.б.ш. тур.). *Киңәшле эш таркалмас, дигәннәр безнең бабаларыбыз.* М.Хәбибуллин. *Димәк, килешү таркала, иң шәп егетләрнең берсе торып кала, дип хафага төшкән [ул].* З.Мурсиев

8) *күч.* Нинди дә булса нормалар бозылу, үтәлүдән туктау. *Әгәр дә бүгенге көндә мәктәп бусагасыннан башланган, күңелгә салып ныгытылган, хакыйкать дип танылган кануннар таркала һәм юкка чыга икән, аның монда ни гаебе бар?* Ф.Яхин

◊ **Таркалып төшү** Юкка чыгу. *Культ һәм торгынлык елларындагы ысулда берләшкән коллективлар, тышкы яктан гына укмаша да, иң беренче сынау вакытында ук таралып, таркалып төшә.* М.Юныс

**Таркала бару** Торган саен акрынлап таркалу. *Череп таркала барган сарай тәрбия ысулына безнең тормышыбызда урын юктыр.* Г.Исхакый. *Зиһеннәре сау чакта намуслары тотмагач, инде хәзер, акыллары таркала барганда гафу үтенерләр, дисезме?* Ф.Яхин

**Таркала башлау** Таркалырга тотыну. *Мөһаҗирләр олавы әнә шулай итеп таркала башлады.* В.Имамов

**Таркала төшү** Бераз таркалу; тагы да таркалу

**Таркалып бару** Һаман акрынлап таркалу. *Гомер буе тир түгеп, бөртекләп торгызылган хуҗалык инде таркалып бара, алда бөлгенлек, ачлык теш ыржайтып тора.* М.Галәү. *Шунысы гаҗәп: бәхет таулары вәгъдә иткән мәхәббәт нигезендә корылган никахларның һәр өченчесе таркалып бара!* Т.Әйди

**Таркалып бетү** Тәмам, тулысынча таркалу. *Менә мондый вакытларда Гыйлаҗи булмаса, без, лачыннан качкан чәүкәләр кебек, таркалабыз да бетәбез.* Г.Ибраһимов. *XV гасырның башларында, Алтын Урда таркалып беткәч, әлеге күчмәннәр Олы Урдага кергәннәр.* И.Хуҗин

**Таркалып килү** Күптәннән бирле таркалу; соңгы арада таркала башлау. *Хәзер генә төшендем: алар бернинди дә яхшыру булмаячагын, алда нинди аяныч көннәр киләсен сизенгәннәр, илнең таркалып килүен, өстә утыручыларның ни кылануларын күргәннәр, аңлаганнар.* Ф.Садриев

**Таркалып китү** Кинәт таркалу. *Чабып бара торгач, бер түмгәккә эләгеп, мичкә таркалып китте.* К.Насыйри. *Ләкин ир тынычлыгын югалтмагач, үзенең фикере таркалып китте.* М.Кәбиров

**Таркалып кую** Көтмәгәндә таркалу. *Әйтик, кайбер күренешләрдә актёрларның көлке детальләр белән артык мавыгып китүләре аркасында ансамбль таркалып куя.* Р.Батулла. *Зур кыенлыклар белән генә оешкан революцион оешма әнә шул рәвешле гел көтмәгәндә таркалып куя.* Р.Мөхәммәдиев

**Таркалып тору** Даими яки әледән-әле таркалу; әле, хәзер таркалу

**Таркалып яту** *сөйл. к.* **таркалып тору**. *Ул планетада үле шәһәрләр, эре индустрия объектлары әкрен генә таркалып ята ---.* З.Мифтахов

**ТАРКАЛЫШ** *и.* 1) Таркалу күренеше. *Радиоактив таркалыш процессын без күрмибез, турыдан-туры сизмибез.* М.Габдрахманов. *Әйе, кызганычка каршы, татарларның бер өлешендә рухи һәм әхлакый таркалыш күзәтелә.* Ватаным Татарстан

2) Тәртипсезлек; бөлгенлек. *Уйлап карасаң, чыннан да, илдә әле Гражданнар сугышы тәмамланмаган, икътисад һәм транспорт өлкәсендә таркалыш дәвам итә ---.* К.Гыйззәтов. *Ике меңенче еллар башында хуҗалык таркалыш кичерә, хезмәт хакын тоткарлык белән бирәләр, елга ике тапкыр.* Тәтеш таңнары

**ТАРКАТКЫЧ** *с.* Тарката торган. *Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен, Истереп, милләтнең берләшү юлын кистермәсен!* Г.Тукай. *Күп кенә материалларда саентология оешмалары таркаткыч дип бәяләнде.* Ватаным Татарстан

**ТАРКАТУ** *ф.* 1) Җимерү, таркау итү. *Дүрт-биш көн эчендә алты миномётыгыз шартлады, Берлинга барып җиткәнче, берсе дә калмаячак, полкны таркатырга кирәк, дип җанга тияләр.* С.Поварисов. *Газнәвиләр династиясенә нигез салучы Мәхмүт Һиндстанга берничә мәртәбә яу белән бара, аның күп кенә өлешләрен җимерә, тарката.* Гасырлар авазы

2) Тарату, исраф итү. *Малны таркатмыйк дип, хуҗабикә каравылчылардан баш тартып, дүртәвесе генә шул йортта яши калдылар.* Р.Батулла. *Ызгышып, мал бүлеп ятып, нинди дәүләтне таркатканнар бит.* Р.Сәгъди

3) Берәр төркем эчендә, оешмада таркаулык тудыру, яшәп килгән иҗтимагый тәртипне бозу. *Козгын Вәли – --- бригаданың эшен таркатырга тырышучы кулак.* М.Җәлил

4) Вак өлешләргә аеру, юк итү. *Бу дару кан тамырларын йомшартучы матдә молекуласын тарката.* А.Тимергалин

5) *хим.* Химик матдәләрне ваграк состав өлешләренә аеру. *Ун диюгә, мин сезгә үземнән импульс-биотокларымны җибәрәм, ул --- токсин, нитратларны таркатып чыгара торган һәм сез белгән, белмәгән авыруларны да дәвалый...* Н.Хәсәнов. *[Кеше] Үз-үзеңне хәтта бетерерлек Көч тупладың, атом таркатып.* И.Гыйләҗев

6) *мат.* Берәр санны берничә санның тапкырчыгышы яки суммасы рәвешенә китерү. *Шахмат программасы бу борынгы уенны алгоритмга таркатып, гап-гади уенчыкка әйләндергән.* А.Тимергалин. *Тамырлары булган квадрат өчбуынны тапкырлаучыларга таркату ---.* Алгебра

7) *лингв.* Сүзне иҗек, тамыр, кушымча кебек кисәкләргә бүлү. *Мәсәлән, латинчадан «интеллигенция» сүзен иҗекләргә таркатыйк ---.* Ф.Мөслимова

8) *күч.* Моң, сагыш һ.б.ш. берәр тискәре хис яки халәттән котылу, арыну. *Кич белән Садри, казарма эчендә хөкем сөргән күңелсезлекне таркату уе белән, шаяру рәвешендәрәк: «Скрипканы да ватып әрәм иткән бит тинтәк!» – диде.* Ш.Камал

**Тарката бару** Берәмләп эзлекле рәвештә таркату

**Тарката башлау** Таркатырга тотыну. *Агулы гөмбәләрдәге матдәләр кешенең бавырын һәм бөерен тарката башлый, баш мие һәм йөрәк эшчәнлеген боза.* Биектау. *Чөнки вирус организмны үзен сиздертмичә генә тарката башлый.* Кызыл таң

**Тарката тору** Әлегә таркату. *Әдәбият гыйлеменең, көндәлек тәнкыйтьнең бары тик юбилейлар уңаеннан гына «җанланып» алуы иҗади шәхесне рухи тарката торды ---.* А.Хәлим

**Тарката төшү** Бераз таркату; тагын да таркату

**Таркатып ату** Көтмәгәндә, тиз арада таркату. *Бер ояга кушам, бер бәйләмгә төйним, дигән булып, абый бар татар дөньясын кырмыска оясы урынына чәчкәләп вә таркатып атты.* В.Имамов. *Әгәр дә без аларны бер-берсеннән аера башлыйбыз икән, ул вакытта кеше җанын да таркатып атабыз ---.* Ф.Яхин

**Таркатып бетерү** Тулысынча таркату. *Ә син иң алдынгы колхозны таркатып бетерә яздың.* В.Нуруллин. *Сигезенче «Б»ны тәмам таркатып бетердең бит инде.* М.Маликова

**Таркатып җибәрү** Кинәт яки бераз таркату. *Мичтә утын ягып, утлы күмерләре генә калгач, бераз таркатып җибәр.* К.Насыйри. *«По места-а-м!» дигән команда, кинәт тыныч күк йөзен телеп үткән күк күкрәве кебек, аның уйларын таркатып җибәрде.* С.Поварисов

**Таркатып килү** Күптәннән бирле даими рәвештә таркату. *Аны шул алда әйткән ярты-йортылык, дин өчен мәҗбүри булмаган либерализм эчтән таркатып килә төсле.* Н.Шәфигуллин

**Таркатып ташлау** *к.* **таркатып ату**. *Ул үзен хәтерсез элементларга тикле таркатып ташлый алыр иде!* А.Тимергалин

**Таркатып тору** Даими яки әледәнәле таркату; әле, хәзер таркату. *Термитлар корыган агач кәүсәләрен һәм коелган яфракларны бертуктаусыз таркатып торалар ---.* Башлангыч география курсы

**ТАРКА́У** *с.* **1.** 1) Таралган, таркалган, тәртипсез, сибелгән. *Көннәр елдагыча эссе булып, ачык зәңгәр күктә төшкә таба таркау болытлар күренгәләп, төштән соң шул үзләре йөзеп йөргән тирән һава диңгезендә эреп, күздән югалалар иде.* Г.Рәфикый

2) Төрле җиргә таралган. *[Коммунарлар] көндезен таркау булалар. Кайсы чабынлыкта, кайсы басуда да була.* Ш.Камал

3) Оешмаган, берләшмәгән; бердәм түгел. *Йосыф абзасы Шәехмамай бәк вафатыннан соң тәхетне үз кулына алса да, илендәге таркау мирзаларны берләштерә алмады.* Р.Батулла. *Гаиләбезнең шундый таркау, туганлык җепләре белән беркетелмәгән булуында әти һәм әни арасындагы салкынлык сәбәп булмадымы икән?* Р.Габделхакова

4) Начар, түбән дәрәҗәдәге; оештырылмаган (эш барышы тур.). *Кайда эшләр таркаурак булса, [Мусаны] шунда җибәрә башладылар.* Ш.Маннур. *Мөхәммәдьяр актив иҗат иткән кырыгынчы елларда илдә тынычлык бетә: илнең экономикасы таркау хәлгә килә, халыкның яшәү шартлары начарлана.* Татар әдәбияты тарихы

5) *махс.* Төрле якка тигез итеп сибелгән, таралган, диффуз. *Астрономиядә котып балкышларын өч төркемгә бүлеп карыйлар: тасмасыман, диффуз (таркау) һәм нурларсыман балкышлар.* А.Тимергалин

6) *сир.* Җыйнаксыз, тотрыксыз (кеше гәүдәсе тур.). *Әхми зур таркау гәүдәсе белән кузгалды.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Эзлексез, бәйләнешсез, чуалчык. *Әкренләп Дамирның миендәге таркау хәлдә булган уйлары тәртипкә салына башлады.* И.Хуҗин. *Беренче батарея командиры Исхаковның чыгышы барлык командирларның таркау фикерләренә нокта куйды.* С.Поварисов

8) *күч.* Дикъкатьсез, игътибарсыз; тупланмаган. *Гүя кәефе яхшы, акылы ачык вакытта таркау уйларын җыярга, әйтәсе сүзләрен хәтеренә төшерергә тырыша [ана].* Ә.Еники. *Аның йөзе уйчан, игътибары таркау иде.* Ә.Хәсәнов

9) *күч.* Эш-гамәлдә эзлеклелек, система, төгәллек сакланмаган, оешмаган. *Югалмас. Үзең беләсең, безнең Зөһрә бераз таркаурак бит. Баласы да булгач...* Ф.Яруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Төрле урында, тәртипсез булып. *Галим гадәтенчә һәрвакыт таркау ята торган эш коралларын эзләми.* Ялкын

2) Оешмыйча, бердәм булмыйча. *Зур дәүләт эшлеклесе һәм оста полководец буларак, Чыңгыз хан элек таркау яшәгән монгол кабиләләрен бер бөтен дәүләткә туплавы белән уңай эш эшли.* Р.Фәхретдинов

3) Эзлексез, бәйләнешсез итеп. *Кырык-кырык ике яшьләрдәге әзмәвердәй таза ир беренче сүзләрен кыюсыз һәм таркау башлап китте ---.* В.Имамов. *Зиһенен җыярга өлгермәгән хайван табибы таркау гына җавап бирә ---.* Т.Нәҗмиев

4) Игътибарсыз итеп. *Илсөяр Җәүһәр белән бик таркау сөйләште.* Ф.Яруллин

5) Эленке-салынкы. *Таркау эшләү*

**3**. *и. мәгъ.* Таркаулык. *Таркалмаган илләремә Таркау керттең, һай син, бала!* Н.Исәнбәт

**ТАРКАУЛАНУ** *ф.* Таркауга әверелү, таркау хәлгә килү; таркау, тәртипсез булып китү. *Таркауланды, бернічә иптәшенә тупас кына эндәшергә дә өлгерде [ул].* Т.Әйди

**Таркаулана бару** Акрынлап таркаулану. *Хәзерге чорда безнең илдә бара торган яшәү өчен көрәш, җәмгыятьтә үз-үзеңне генә ихтирам итү хисенең көчәя, коллективларның таркаулана баруы --- яшь кешенең якты омтылышларын сүндерә, үзенә тиешле тормыш юлы сайларга комачаулый.* Безнең гәҗит

**Таркаулана башлау** Таркауланугa таба бару. *Шуннан түгәрәк бер нәтиҗәгә килде бугай төптәнрә: хан чынлап та картайган, зиһене, акылы таркаулана башлаган.* М.Хәбибуллин

**Таркаулана төшү** Бераз таркаулану. *Аның җитез һәм дәү адымнарына өлгерә алмаган кәҗә көтүе инде шактый сузыла, таркаулана төшкән.* Р.Мөхәммәдиев

**Таркауланып бетү** Бик нык таркаулану. *Безгә хәзер ничә еллар үзара сугышып, таркауланып беткән милләтне дин һәм бөек тарих белән берләштерергә, ныгытырга кирәк.* Ф.Бәйрәмова

**Таркауланып китү** Кинәт таркаулану. *Соңгы вакытта минем бик нык таркауланып китүем аңа да барып ирешкән иде булса кирәк, шунлыктан ул карышып тормады ---.* З.Мәхмүди. *Кинәт таркауланып киттем, әйләнә-тирәне күрмәс, шәйләмәс булдым.* М.Юныс

**Таркауланып тору** Вакытлыча таркаулану; әле, хәзер таркаулану

**ТАРКАУЛЫК** *и.* 1) Таркалганлык, таркау булу хәле. *[Командирның] артыннан шундый ук тизлек, ләкин зур таркаулык белән эскадрон да китте.* А.Шамов

2) Тәртипсезлек. *Хәтта идәндә дә китаплар өелгән иде. – Сез бу таркаулыкка игътибар итмәгез, – диде карт.* Г. Әпсәләмов

3) Бердәмсезлек, оешмаган булу. *Баш күтәрүчеләр арасында туган таркаулыкны дошман тиз сизенде.* В.Имамов. *Мин Гали абыйны башта аңлап бетермәдем, бүленеп чыгып таркаулык китерә бит бу, дип уйладым.* З.Зәйнуллин

4) Эзлексезлек, бәйләнешсезлек, чуалчыклык. *Әмма бу әсәрдә әлеге образ тирәсенә тупланган хәл-вакыйгалар художестволы бербөтенне тәшкил итмиләр, нииндидер таркаулык үзен сиздерә.* М.Кәбиров. *Элеккегечә тыныч һәм катгый кыяфәт белән утырса да, киңәшмәнең калган өлешендә Җангир тәки фикер таркаулыгыннан арына алмады.* Ә.Дусайлы

5) Сәламәт, нормаль эшләүдән туктау. *Зиһен таркаулыгы чире йоктымы соң миңа?* А.Хәсәнов

6) Эшне тиешенчә, тәртип белән эшли алмау күренеше. *Бүлмәдә дә, кухняда да аунап яткан кәгазьләр, хатынының таркаулыгы, тәртипсезлек Вилданның эчен пошыра иде.* М.Маликова

**ТАРКА́У-ТАРКАУ** *рәв.* Таркалган хәлдә, аерым-аерым, төркем-төркем булып. *Безнең халык тарткалашып, Таркау-таркау көн итми.* М.Җәлил

**ТАРЛАВЫК** *и.* Таулыкларда, таулы урыннарда текә ярлы тар үзән. *Алар ишелергә торган кыя төбеннән, тарлавыклардан, судан яртылаш кына чыгып торган ташларга сикерә-сикерә үтеп, коточкыч бер көч белән коелып торган шарлама янындагы тау тишегенә килеп керделәр.* Г.Әпсәләмов. *Тарлавык авызына чаклы бер көнлек юл.* А.Хәсәнов

**ТАРЛАН** I *с. к.* **таргыл**. *Аяклары көмеш чылбыр белән бәйләнгән ау карчыгалары – кайсысы күн беләксәгә баскан, кайсысы тугры агачка кунаклаган торымтайлар, җүрү козгын, саңсар бөркет, тарлан карчыгалар җилпенепҗилпенеп ала.* Р.Батулла

**ТАРЛАН** II *и.* **1.** *диал.* Сөрелгән, эшкәртелгән җир. *Тарландагы тартай, кырдагы куян.* Әйтем

**2.** *с. мәгъ.* Сөрелгән, сөреләә торган. *Тарлан җирне саз йотмас.* Мәкаль

**ТАРЛАНУ** *ф. сир.* 1) Берәр нәрсәнең булуына яки берәр сыйфатта булуына ачу белдерү, тарсыну. *Фатыйма апай тарлана һәрнәрсәгә. Һәм диер: бу нәрсәгә, бу нәрсәгә?* Г.Тукай. *Шулай булгач, ничек без сандугачлар инде зарланмыйк, Күңелсез, тар бу тормыштан разый булыйк та тарланмыйк?* Г.Шәрифи

2) Тартыну, уңайсызлану. *Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, би, ти, си, җымыкый»ны бер дә тарланмыйча кычкырып укый башладым.* Г.Тукай

3) Берәр сәбәп белән яисә гомумән кәефсезләнү, эшли алмыйча һ.б. йөрү. *Уйлыйм-уйлыйм – уйның рәтен тапмыйм, Әллә нәрсә җитми – тарланам.* Ф.Бурнаш. *Ялгызы гына тарланса, ник шартламый абзыкай.* Т.Әйди

**Тарланып бетү** Тәмам, бик нык тарлану. *Тарланып бетте дөньям*

**ТАРЛА́У** *и.* 1) Болын яки урман уртасындагы басу. *Тана бозау тарлауда, үгез бозау үләндә.* Мәкаль. *Олысы-кечесе тарлауда арпа чәчәләр.* И.Диндаров

2) Басу уртасында сазлы яисә куаклы булу сәбәпле сөрелми калган җир. *Әнә аерым тарлау булып тал әрәмәсе утыра.* А.Гыйләҗев

**ТАРЛЫГУ** *ф.* Кыенсыну; рухи кыенлык кичерү. *Җәүдәт өчен үлем дә яшәми иде, хәл эчендә ятканда да җаны тарлыкмады.* М.Шабай. *Таш калада тарлыккан җаннарны Киңәйтә шул таныш киң кырлар.* Л.Шагыйрьҗан

**ТАРЛЫК** *и.* 1) Тар булу, иңгә кыска булу, киңлеге аз булу хәле. *Элек тә ул Акъяр хастаханәсенең искелегенә, кысанлыгына бик борчыла иде, шәһәрдәге зур хастаханәдән соң мондагы тарлык аны аеруча әрнетте.* Г.Әпсәләмов

2) Кыскалык, урын аз булу күренеше. *Астыңда нибары юка палас кына я бишмәт чабуы гына икәнлеге дә, урын тарлыктан аякларыңны сузып әлиф ятуың да онытыла.* Г.Бәширов

3) Комачау, киртә, каршылык; зыян. *Хәер инде, сезнең дөньяга сыймаган зур куанычыгызга тарлык ясыймындыр шул.* М.Фәйзи

4) Чикләнгәнлек. *Бу арада ул сулыш тарлыгыннан башка бернәрсә дә хис итми иде.* Ш.Камал. *Председатель Әхмәдулла, билгеле, үзен озак көттерүне яратмый, кырык эшен барлап, вакыты тарлыгын күрсәтмәкче була.* В.Имамов

5) Кыенлык, мохтаҗлык, кытлык; фәкыйрьлек. *Шул тарлыкта нәкъ алты ел узып китте, Амбарлардагы ашлыклар тәмам бетте ---.* Кол Гали. *Шундый тарлыкта яшәгән бөек рәссамның юмартлыгына сокландым...* Г.Гомәр

6) Ризасызлык; тарсыну сыйфаты. *Әмма адәм баласына андый тарлык килешми.* Р.Вәлиев. *Китәм, ди бит әнә. Күңелеңнең тарлыгына үләрсең!* Н.Гыйматдинова

7) Билгеле сыйфатларның җитмәве, түбән дәрәҗәдә булуы, сайлык. *Эрудициянең сайлыгы һәм тарлыгы үзен бигрәк тә җитди музыка әсәрләрен зиһенгә алуда күрсәтә.* К.Гыйззәтов

**ТАРЛЫ́К КЫЛУ** *ф.* Кысу, чикләү, киртә ясау. *Гаилә яшәеше хосусында тарлык кылалар, фәкыйрьләргә золым итәләр, ятим вә зәгыйфьләрнең хакларын ашайлар.* Г.Бубый. *Мәгәр «канымыз Чыңгыздан килә» дип мактанучы кайбер кабиләләр соңгы заманнарда җир-суга тарлык кылып, үзләренең җәберләрен арттыра башладылар.* Г.Ибраһимов

**ТАРМА** *и.* 1) Кыргый киндераш, чәчелми үсеп чыккан киндер. *Урак өстендә әтием белән әнием миннән бала караталар, көлтәгә баулык тарма йолкыталар һәм учма җыйдыралар.* С.Кудаш // Гомумән киндераш. *Италия сәяхәтчесе Иосафат Барбаро кыпчакларның алга киткән агрокультурасы булуы, бодай, тарма чәчеп зур уңыш алулары турында язып калдырган.* И.Хуҗин

2) Шундый киндераштан сугып алынган майлы орлык. *Тарма бөккәне. Тарма талканы*

**ТАРМАК** *и.* 1) Үсемлекләрнең бер төптән аерылып киткән сабак яки тамыр өлешләре. *Күпләп алмый, өч-дүрт тармак кына, иң матурларын сайлый ул [чәчәкләрнең].* Г.Әпсәләмов

2) Ботак. *Будкага җитәрәк йөз-йөз илле адымда бик күп тармаклы, куе яфраклы бер карт имән бар.* Г.Гобәй

3) *күч.* Бер урыннан аерымланган юл, сулык, тау һ.б.ш.ларның һәрберсе. *Такта заводыннан сузылган җиде километрлык юл тармагы эшчеләрнең, инженер-техник көчләрнең зур тырышлыгы аркасында вакытыннан алда төзелеп бетте.* А.Алиш. *Ханбалыкка җитәбез дигән көннең салкынча таңында гарәп базаргано Фатих ибн Әхмәт каеклары Итилнең төп юлыннан аерылган бер тармакка килеп керделәр.* Н.Фәттах

4) *сир.* Уртак бабадан килгән билгеле бер токым; шәҗәрәдәге аерым бер нәсел дәвамы, тарамык. *Ә син үзең түбән тәгәрәдең дә тоташкан тармакларыңны да иярттең.* А.Гыйләҗев. *Чөнки тәрәзә йөзлекләре юллап килүчеләр әледән-әле үзләренең кем улы, кем кызы һәм кайсы тармактан, кайсы чыбыктан Гыйлемханнарга кардәш тиешлекләре турында да җиткерергә онытмыйлар иде.* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Хуҗалык, җитештерү, фән һәм техниканың бер өлкәсе. *Барысы да – үз тармаклары буенча югары белемле кешеләр.* В.Нуруллин. *Шуңа күрә тармак терминологияләрен эшләүне белгечләргә (химикка, математикка, физикка) калдыру тиеш.* А.Тимергалин

6) *күч.* Берәр өлкәдә барлыкка килгән агым, юнәлеш. *Өстәвенә исламда нусайрияләр тармагы да бар (шигыйлыкта бер радикаль агым), ул чыннан да кайбер христиан дине элементларын үз эченә ала.* А.Тимергалин

7) *күч.* Бербөтенне тәшкил иткән берничә яки күп караш, вакыйга һ.б.ш.ларның һәрберсе, һәр юнәлеше. *Романчыга берничә сюжет тармагын ияртеп барырга кирәк.* Ф.Хатипов

**ТАРМАКЛАНУ** *ф.* 1) Тармак-тармак булу; тармак рәвешен алу, тармаклар җибәрү. *Шушы вакытта Гөлбануларга каршы гына салынган урыс капкалы йортның бердәнбер варисы булган Ихсанбай тармакланып үскән тирәк төбендә Гөлбануны көтте.* Т.Гарипова

2) Тармакларга (*1–3 мәгъ.*) аерылу. *Район үзәге Якты Күлдән, дүрт якка тармакланып, таш юллар сузылып китте.* Г.Бәширов. *Түбән очта, ыштан балаклары булып, Олы урам икегә тармаклана.* А.Гыйләҗев

3) Тармаклары күбәю, берничә өлкәгә аерымлану (хуҗалык, фән һ.б. тур.). *Комбинат, тармакланып, дистәләрчә мең кешегә эш, әллә ничә посёлокка һәм шәһәргә җан биреп торучы организм иде шул.* Кызыл таң

4) *күч.* Җәелү, яңа юнәлеш алу. *Бу этапта романның Фәхринең үтерелүе белән башланган сюжеты төрле якка тарала, тармаклана, үсә һәм катлаулана.* М.Хәсәнов. *Әйе, иш-иптәш белән әңгәмә-бәхәсләрдә фикерләр тармаклана.* М.Хуҗин

◊ **Тармакланып үсү** Күпьяклы булып, гөрләп үсү (иҗтимагый һ.б. күренешләр тур.). *Октябрьдан соң пролетариат язма әдәбиятының киң күләмдә иркенләп, тармакланып үсүенә юл ачылды.* М.Җәлил

**Тармаклана бару** Торган саен күбрәк тармаклану. *Социализм төзелешенең тирәнәя, тармаклана баруы без-*

*нең алдыбызда яңадан-яңа сораулар, яңадан-яңа мәсьәләләр тудырып тора.* Һ.Такташ. --- *кешелекнең шәҗәрә агачы үсә, киңәя, тармаклана барган.* Р.Низами

**Тармаклана төшү** Берникадәр тармаклану

**Тармакланып бетү** Бик нык тармаклану

**Тармакланып килү** Акрынлап тармаклана башлау

**Тармакланып китү** Кинәт тармаклану; тармакланып дәвам итү. *Бәләкәй әрәмә янында олы юлдан уңга тар гына икенче юл тармакланып китте.* Н.Фәттах. *Бәхет, мал, бәрәкәт, әллә ничек кенә шунда, өй тирәсендә йөргән кебек итте дә, эчкәрәк үтеп, тармакланып китә алмады.* Г.Бәйрәмова

**Тармакланып тору** Туктаусыз тармаклану; әле, хәзер тармаклану. *Агач ботагыдай тармакланып торган зур мөгезле поши үзенең матур һәм моңсу күзләре белән балаларга карап тора.* Ә.Фәйзи

**ТАРМАКЛАП** *рәв.* 1) Тармакларга (*5 мәгъ.*) бүлеп. *Тармаклап сатып алу тәҗрибәсе*

2) Төрле яклап. *Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды [ул].* Г.Ибраһимов

**ТАРМАКЛА́У** *ф.* Тармакларга аеру; тармаклы итү, тармак-тармак ясау. *Сул кулында – бер бауга тармаклап бәйләгән ике яшь тай.* В.Имамов. *Аккөмес – әллә ничә тармаклап үргән кара чәче тубыкларынача төшеп торган бик аз сүзле бер кыз иде.* Казан утлары

**ТАРМАКЛЫ** *с.* 1) Тармакланган; тармаклары булган. *Дөрес, моннан соң алынган фоторәсемнәрдә Марста кайчандыр елгалар аккан бормалы һәм тармаклы үзәннәр, тирән каньоннар ачык күренә.* А.Тимергалин. *Һәм шул мизгелдә үк Пират ---, нәкъ чын бүре кебек, куе тармаклы чыршы агачы очына карап улап җибәрде.* З.Хөснийяр

2) Күп тармаклар бирә, нык тармаклана торган; бер сабактан берничә баш чыгара, берничә башак бирә торган. *Тәҗрибә участогына кукуруз, тармаклы бодай һәм төрле гөлләр чәчелде.* Кайбыч таңнары

**ТАРМА́К-ТАРМАК** *с.* **1.** Тармаклар рәвешендәге; бик нык тармакланган. *Яфрак астыннан, чыклы үләннәргә баса-баса, озын колаклы куян чыга; тармак-тармак мөгезле башын югары күтәреп, юеш борыны белән салкынча һаваны исни-исни, урман сыеры су эчәргә китә.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тармаклар рәвешендә. *Ботаклары тармак-тармак җәелгән карт артыш куагы икән, мылтыгын алам дип иелгән иде, карашы уртадагы юан гына ботак төбенә бәйләнгән чүпрәккә төште.* Ә.Әминев

**ТАРМАКЧА** *и.* Тармакның тармагы. *Бер кәүсәдә йөз ботак, һәр ботакта унике тармак, һәр тармакта утыз тармакча.* Табышмак

**ТАР-МА́Р БУЛУ** *ф.* 1) Теткәләнү, туздырылу

2) Җимерелү; юкка чыгу. *[Хан:] Юк, мин үлгәч, бу йорт, бу ил Тар-мар булмасын.* Н.Исәнбәт

3) Җиңелү, кырылу

**ТАР-МА́Р ИТҮ** *ф.* 1) Туздыру, теткәләү; вату-җимерү. *Хатыны каршы чыгып: «Һи, син кайда йөрисең? Әсбапларымызны җил тар-мар итте», – дип шикаять кыйлды.* К.Насыйри. *Мөдирлек кулыңнан ычкынгач, синең нәрсәдер җимерәсеңне, тар-мар итәсеңне көтә идем.* А.Гыйләҗев

2) Юк итү, җимерү. *Март урталарында Тәтеш өязенең Урта Балтай волосте Чатбаш авылы крестьяннары җир биләүче Бикбулатовның йортын һәм усадьбасын тар-мар иткәннәр.* М.Хәсәнов

3) Җиңү, оту; кырып ташлау. *Дошманны үз җирендә тар-мар итәрбез, дип, сугышка кадәр күпме антлар бирде ул.* Г.Әпсәләмов. *Ә Харьков янында немецлар «капчыкка» эләккән өч армияне тар-мар итеп, 1,5 миллионга якын кешене әсирлеккә алалар.* З.Зәйнуллин

**ТАР-МА́Р КИЛҮ** *ф. к.* **тар-мар булу**. *Майя белән Сарымбәт каберennән гайре һәммә нәрсә юк ителә, яндырыла, тар-мар китерелә.* Р.Фәхретдин

**ТАРМА́ ТУРГАЕ** *и. к.* **киндер чыпчыгы**

**ТАРМА́Ч** *и. диал.* 1) Баш-башына резинка тарттырылган ике япьле ату коралы; рогатка, сапкан. *Малайлар тармачтан таш белән аталар*

2) Тырпаеп торган мөгез, ботак һ.б. тармаклары. *Корыган агач тармачлары*

3) Ике япьле агачтан гыйбарәт тормоз җайланмасы. *Арба тармачы*

**ТАРМА́ ЧЫПЧЫГЫ** *и. к.* **киндер чыпчыгы**. *Кош аулаучы базарга бик күп кошлар китергән. Песнәге дә бар, чыпчыгы да, кычыткан кошы да, тарма чыпчыгы да – барысы да бар.* Ак юл

**ТАРПАН** *и. төрки* Көнчыгыш Европада тереклек иткән, XIX гасырда үтереп бетерелгән борынгы кыргый ат. *Кеше гасырлар дәвамында шушы хайванны үзенә ияләштергән, хезмәткә өйрәткән, кыскасы, кыргый тарпаннан асыл дустына, хезмәттәшенә, йорттәшына --- әверелдергән.* Гасырлар авазы

**ТАРПУ** *ф. к.* **тарбану**. *Тарсынган хуҗадан биз, тарпыган аттан биз.* Мәкаль

**ТАРС** *иярт.* **1.** Шартлап дөпелдәү авазын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып; кисәк шакылдатып. *Баһау ишекне тарс ябып чыгып та китте.* Г.Минский

**ТА́РС ИТҮ** *ф. к.* **тарсылдау**. *Ишек тарс итте*

**ТАРСЫЛДАТУ** *ф. йокл. юн. к.* **тарсылдау**. *[Бикташ карт] берданкасын һавага күтәрде һәм, курыкканнарның котын алу өчен, тарсылдатып атып та җибәрде.* Г.Минский

**ТАРСЫЛДА́У** *ф.* 1) Тарс итү, дөпелдәү һәм шатырдау (икесе бергә). *Ишек, шартларга җитешеп, тарсылдап ябылды.* И.Туктар

2) Бик еш, нык тибү (йөрәк тур.). *Йөрәк дигәнең, читлеккә эләккән тиен кебек, тарсылдап сикерә.* Ф.Хөсни. *Адәм белән Хәүва биюе дә, оҗмах җимешләре дә ымсындыра, --- тарсылдаган йөрәгең, читлеккә килеп эләккән кош кебек, саф һавалы урамга ашкына.* Т.Әйди

**ТАРСЫНУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса тар дип исәпләү, нәрсәнең дә булса тар булуыннан канәгать булмау. *Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы; Шат яратса да, җиһанга ят*

*яраткан раббысы.* Г.Тукай. *Нәфисә, үз койкасына ятарга дип, ишектән кергәндә, нигәдер келәт эчен тарсынды.* Г.Бәширов

2) *куч.* Нәрсәне дә булса бөтен барлыгы белән уңайсыз, рухка яраксыз дип табу, шулай тою. *Мин, ирек теләп, атам йортын тарсынып чыгып киткән кыз.* М.Фәйзи

3) *куч.* Төрле сәбәпләрнең берьюлы тәэсире нәтиҗәсендә авыр хисләр кичерү; борчылу. *Эче пошты, күңеле тарсынды [Шәмсинең].* Г.Исхакый. *Җан, тарсынып, сөенеч эзләгәндә, чит кайгылар авыр тоелмый бит ---.* А.Гыйләҗев

4) *куч.* Нәрсәнедер яки кемнедер кирәксенмәү, артык күрү; яратмау. *Хуҗасы тарсынса, кунагы тартыныр.* Мәкаль

5) *куч.* Уңайсызлану, тартыну. *– Без хәзер генә аналы-кызлы эчкән идек, кунакларны яхшылап эчер... Ашка да җитегез, балакай, тарсынмый гына аша, эчегез, – диде [ул].* Ш.Камал. *Туры карарга тарсынасың бугай, күзеңне яшерәсең, я, нинди йомыш китерде миңа сине, турысын әйтеп сөйлә.* В.Имамов

**Тарсына башлау** Тарсынырга тотыну. *Аның артыннан шул аулакка кереп, Зөбәйдәгә кул сузудан, үбәргә омтылудан да тарсынмый башлады [Миңнехан].* В.Имамов

**Тарсына төшү** Бераз тарсыну

**Тарсынып алу** Азрак тарсыну. *Береаздан айнып, Айгөл Җәүдәтовна тарсынып алды.* Ф.Яхин

**Тарсынып китү** *к.* **тарсынып кую**. *Тарсынып китте күңел шунда ---.* Б.Мирзанов

**Тарсынып кую** Кинәт тарсыну

**Тарсынып тору** Вакытлыча тарсыну; әле, хәзер тарсыну. *Күзәмеш бераз тарсынып торгач, кинәт кенә «изге сүзләр» әйтеп кычкыра башлый, сикеренә, кыргый хәрәкәтләр ясый...* А.Гадел

**Тарсынып яту** *сөйл. к.* **тарсынып тору**. *Гостиницадагы тарлыктан, бигрәк тә ят ирләр, ят кешеләр арасында оялган хәлдә тарсынып яту түгел иде инде бу.* С.Рафиков

**ТАРТАЙ** *и. к.* **тартар** I. *Тартай теленнән табар.* Мәкаль. *Тартай, бүдәнә кычкырса, яңгыр булыр.* Сынамыш

◊ **Тартай кебек** Бик ябык, какча гәүдәле. *Шулай итеп, мин сабан бетергәнче тартай кебек арыкладым.* М.Гафури

**ТАРТАЛА** *и. гади с. к.* **тамтарарай**. *[Бәдри:] Микалай [патша] тарталага киткән. Аның сурәтләрен аяк астына салып таптадык.* Х.Кәрим

**ТАРТАР** I *и. зоол.* Көтүче кошлар семьялыгыннан үлән арасында яши торган көрәнсу җирән төстәге кечерәк кенә йөгерек кош. *Арпа елгасы ягыннан тартар белән бытбылдык тавышы ишетелде.* Г.Бәширов. *Кай тарафтадыр тырышып-тырышып тартар кычкыра, ул да түгел, тартарга ияреп диярлек байгыш ухылдап куя.* М.Хәбибуллин

◊ **Тартар арбасы** *шаярт.* Кечкенә йөк автомашинасы. *Хәзер без «тартар арбасы» дип көлеп кенә карарга гадәтләнгән «полуторка» машинасы --- сирәк кунак иде бу юлда.* Р.Төхфәтуллин

**ТАРТАР** II *и. фр.* Каты пешерелгән йомырка сарысы, үсемлек мае, яшел суганнан ясала торган традицион салкын соус; татар соусы. *Тартар соусының рецепты*

**ТА́Р-ТАР** *иярт.* Торна, тартар һ.б.ш. кошларның каты һәм кискен итеп кычкыру тавышын белдерә. *Тартар гомере тар-тар дип үтәр.* Мәкаль

**ТАР-ТА́Р КИЛҮ** *ф.* Тар-тар иткән тавышлар чыгару (торна, тартар тур.) *Мин, карга, каргылдыйм, тартай тартар килә, чыпчык чыркылдый, бака бакылдый, торна, әле авып бетмәсәк тә, торыйк-торыйк, дип аваз салырга тотынды.* Ф.Дәүләтбаев

**ТАРТАРЧЫ** *и. иск.* Нефть суыртучы эшче. *Ярлыларны Баку да елмаеп кына каршы алмаган. Сөрем каплаган куышлыкларда торучы тартарчылар төрле авырулардан чебен кебек кырылганнар.* М.Хәсәнов

**ТАРТКАЛАШ** *и.* 1) Этеш-төртеш. *Ресторанның ишек төбендә тарткалаш, нindидер бәргәләш чыгып алды.* Н.Акмал

2) Бәхәс, тарткалашу, сүз көрәштерү

3) Көрәш; талаш, ызгыш. *Гомер бакый тарткалаш бара шул тәхет тирәсендә.* Ф.Сафин

**ТАРТКАЛАШУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса бер-берсеннән тартып алу яки бер-берсен кая да булса алып китәргә теләп үзара тартышу. *Малайлар һәркайсы алгарак эләгергә тырышып тарткалаша, төрткәләшә башлады.* З.Зәйнуллин. *Мескен сыер туктаусыз артына каерыла, дүрт аягы белән карышып тарткалаша, мөгрәп акырган бозавын калдыра алмый, җан тетрәткеч тавыш белән кычкыра...* Т.Гарипова

2) Көрәшү, көрмәкләшү, көч сынашу. *Барып җитсәм, исем китте: урман юлы өстендә Сәйфи белән Шәмсетдин абый тарткалашалар.* Г.Бәширов. *Дошман белән якага-яка килеп тарткалашкан көннәрдә дә, үлемнең күзенә туры карап утка кергән сәгатьләрендә дә бүгенгедәй ару-талу, бүгенгедәй өметсез төшенкелеккә бирелгәне юк иде аның.* Р.Мөхәммәдиев

3) Берәр нәрсә өчен дәгъвалашу. *Байтак кына тарткалашып, ахырында ике йөз сумга килештеләр.* М.Галәү

4) *куч.* Сүз көрәштерү, бәхәсләшү; риза булмыйча, сүзгә килү. *Безнең җирдә бик зур эштән бәхәс ачып, Торалар ушбу көндә тарткалашып; Мизанның табаклары күтәрелгән, Ахырында кайсы тараф китәр басып.* Г.Тукай. *Билгеле, аның Данияр белән бу мәкалә турында чак кына тарткалашасы, бәхәсләшәсе, үзенең дә бөтенләй үк надан, төшеп калган түгеллеген күрсәтәсе килгән иде дә, тик мәкаләдә андый урын табылмады.* М.Хәсәнов

**Тарткалаша башлау** Тарткалашырга тотыну. *Әйләнмәнең уртасына җиткән вакытта икенче урынны алу өчен, ул тагын Гарифҗан белән тарткалаша башлады.* Н.Яһудин

**Тарткалаша төшү** Аз гына тарткалашу

**Тарткалашып алу** Бераз тарткалашу. *Йорт хуҗасы Йомык Минсаф белән Нурдидә кайбер көннәрдә, «койма колаклары»н уйлап тормый, хәтта ишегалдында да тарткалашып ала.* В.Имамов. *Аннан ары болар үтүк өчен тарткалашып алды әле!* Р.Гаязетдин

**Тарткалашып бетү** Тәмам, бик нык тарткалашу; эш тарткалашуга ук барып җитү

**Тарткалашып килү** Билгеле бер вакытка кадәр тарткалашу. *Көздән бирле мин болар белән тарткалашып килдем.* Ш.Камал

**Тарткалашып китү** Көтмәгәндә тарткалаша башлау. *– Туп миңа тиеш! – дигән. – Юк, миңа тиеш! – дигән. Тарткалашып киткәннәр, Әүмәкләшеп беткәннәр.* Ш.Галиев. *Сәхнәдә уйнаганда, Фатыйма Ильская белән Мохтар Мутин чынлап тарткалашып китә.* Р.Батулла

**Тарткалашып тору** Даими яки әледән-әле тарткалашу; әле, хәзер тарткалашу. *Шуннан соң да аның белән тарткалашып торуның мәгънәсе юк иде.* В.Нуруллин. *Тарткалашып торырга ирек калдырмады, тотты да мине мәгариф бүлегенә эшкә күчерде.* В.Имамов

**Тарткалашып яту** *сөйл. к.* **тарткалашып тору**. *Хәзер исә бәхәсләшеп торырга ниятем дә, сәламәтлегем дә юк. Аннан мохтаҗлыгым да мәҗбүр итми, бәхәскә кереп, эш урыны өчен тарткалашып ятырга.* Безнең гәҗит

**ТАРТКЫ** *и. диал.* 1) Кар, ашлык кебек сибелүчән, чәчелүчән нәрсәләрне эләктереп күчерү өчен көйләнгән такта җайланма. *Шәфикъ кара турыны зерәгә генә җигеп чыкмый, --- базарына да бара, --- бәләкәй тарткы белән кар да тарттырган була.* Г.Толымбай

2) Түшлек, бавыргалык. *Ул якында гына чана тарткыларын, кошовка тәртәләрен төзәткәләп йөри булып чыкты.* Ф.Яхин

3) Ыштан бавы урынына кидерелә торган резин // Оекны бот төбеннән буып тота торган резин; бугыч

4) Төрле корылмалар, җиһазлар таралып китмәсен өчен куелган эләктергеч; *русчасы:* **скоба**. *Кереп утырмакчы иде, өстәл атынмасын өчен кагылган тимер тарткыга чалбары эләкте, умырылып та төште.* Р.Газиз. *И-и, авыл малаена эш бетәмени ата-ана йортында, туган нигезеңдә: анда терәү салырга кирәк, монда тарткы куярга, тегендә этке ясарга...* Р.Кәрами

**ТАРТКЫЧ** I *и.* Арба, вагон һ.б.ш. нәрсәләрне тартып йөртү өчен зур егәрлекле трактор, автомобиль; *русчасы:* **тягач**. *Танкны платформалы тарткычта Чистайга зур авырлык белән алып кайттылар, куәтле кран ярдәмендә бушаттылар.* Чистай хәбәрләре

**ТАРТКЫЧ** II *и.* 1) Төрле ризыкларны ваклау өчен кул тегермәне, иттарткыч кебек җайланма. *Шуны киптереп, тарткыч аша чыгарып, ашарга яраклы карабодай ярмасы ясадык.* Әгерҗе хәбәрләре

2) Еравктагы әйберләрне тартып китерү коралы. *Мин исә кулыма озын тарткыч тотып, түшем белән шуышып, машина астына кереп киттем. Шунда яткан көе әрҗәдәге утлы шлакны җиргә тартып төшерәм.* Р.Фәизов

**ТАРТМА** *и.* **1.** 1) Өстәл, шкаф һ.б.ш. нәрсәләрдә махсус кысада шуып йөрерлек итеп урнаштырылган һәм тартып чыгарыла торган дүрткел формадагы савыт. *Ул, хатларны җыеп, комодның бер тартмасына салды да, бер нәрсә дә уйламаска тырышып кына, ялкау гына чишенергә тотынды ---.* Ф.Әмирхан. *Ул өстәл тартмасыннан зур блокнот чыгарды да Һашимов әйткәннәрне яза башлады ---.* А.Алиш

2) Дүрткел формадагы һәртөрле капкачлы яки капкачсыз савыт, әрҗә, кап. *Тау-тау булып он, дөге, ярма капчыклары өелеп тора, агач тартмаларда гәрәбә төсле сап-сары йөзем, потлап-потлап ап-ак куй мае иде.* М.Галәү. *Бер катыргы тартмага фотография кирәк-яраклары тутырылган иде.* А.Тимергалин

3) Кузов; чуман. *Чәчүне төнлә бетерәләр, машина тартмасында дүрт центнерга якын орлык кала.* Ф.Садриев. *Мөҗип абыең машинасының тартмасы өй чикерткәсе тавышы чыгара.* Р.Батулла

4) Өстенә боз җәелгән яки чирәм үстерелгән, борт белән уратып алынган махсус спорт мәйданчыгы. *Әгәр киләчәктә һәр мәктәптә хоккей тартмалары, волейбол, футбол командалары булса, тренерлар билгеләнсә, аларга яшьләр белән эшләргә шартлар тудырылса, мондый спортны мин ике куллап хуплыйм.* Р.Вәлиев

5) Стенадагы ишек уемына беркетелеп, күгәннәр белән ишек капкачы ныгытыла торган кыса, ишек блогының бер өлеше

6) *махс.* Төзелеш объектларының төп каркасы, җылылык системасы үткәрелмәгән, ишек, тәрәзәләре куелмаган стеналары һәм түбәсе. *Өйнең тартмасы әзер*

7) Механизмнарның, машиналарның кап, тышча эченә урнаштырылган төрле өлешләренең атамасы. *--- кукрәк кесәсеннән шырпы кабыдай тартмасын да тартып чыгарды аппаратның, ачып карады, тоташкан чыбыкларын да тарткалаштырды...* Ф.Баттал. *Галим белән Зәкия, калын кысалы күзлекләрен киеп, малайларының ян-ягына утырдылар да, җитди кыяфәт чыгарып, шул тартманың --- яшел төймәсенә, кайчан кызылына басарга кирәклеген өйрәнделәр.* Р.Галиуллин

8) *сөйл.* Телевизор. *Тартманы кабызып кино карау*

**2.** *с. мәгъ.* Тартмалап тутырылган; тартма рәвешендә булган. *Йөзәр тонналаган ит, колбаса, мичкә-мичкә тозлаган балык, кызыл уылдык, кара уылдык, йөзәрләгән тартма чәй, шикәр, капчыгы йөзәр килолы кытай дөгесе, алма, лимон, шоколадтыр, печеньедыр һәм тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр.* З.Зәйнуллин

◊ **Тартма төсле** Бик кечкенә. *Тартма төсле кечкенә, тын бер бүлмә ---.* Б.Мирзанов

**ТАРТМАЛАП** *рәв.* Тартма берәмлеге белән исәпләп; тартмалар белән, тартма-тартма итеп. *Ике сарык симертелә, каз-үрдәк бар, күңел юаткычын да ул шәһәрдән тартмалап алып кайтып, базга төшерде.* Р.Батулла

**ТАРТМАЛЫ** *с.* 1) Тартмасы булган. *Комиссионный кибеттән алган зур, сырлы-сырлы юан аяклы, тугыз тартмалы өстәл.* А.Тимергалин

2) Тартмадагы, тартмага салынган, тартмага тутырылган. *Фирдәүсә сумкасыннан тартмалы конфет алып, Әмирҗанга бирде.* Ф.Садриев. *Тәнзилә Рифатка бер кап чәй, тартмалы чәкчәк тоттырды.* Ә.Хәсәнов

3) Тартма эчендә ясалган. *Яшелчәләр һәм куаклар өчен – тартмалы түтәлләр, үрмәле үсемлекләр өчен пергола*

*ясалган; чәчәклек, кечкенә генә газоннар булдырылган ---*. Туган як

4) *әд.* Берсе артыннан икенчесен тезеп биргән, һәр вакыйганы аерым бүлекчәгә чыгарып исемләгән. *Мондый әсәрләрнең күпчелеге аерым бүлекләрдән гыйбарәт, ягъни тартмалы композициягә корыла.* Г.Гайнуллина

5) *махс.* Автомобильләрдә хәрәкәт тизлеген көйли торган механизмы булган. *Автомат тартмалы автомобильләрне тартып йөрергә ярыймы?* Кәеф ничек? *Тик шунысын онытмаска: «АТ» категориясе булган кеше механик тизлек тартмалы машина белән идарә итә алмаячак.* Дуслык

**ТАРТМА́-ТАРТМА** *с.* Бергә торган, бергә куелган берничә яки күп тартмаларга тутырылган. *Ул да түгел, тартма-тартма, капчык-капчык бүләк, савыт-саба, ризык-мазар күтәргән Хәйруллин үзе, Татар телевидениесе, һәртөрле агентлык журналистлары килеп тә җитәләр ---*. Ф.Яхин. *Ямьле яз, җәй айлары җитүгә, чоланга җыелган тартма-тартма буш савытларны бакча артындагы Сәлмән чишмәсе буена илтеп түгә малай.* А.Хәйретдинова

**ТАРТМАЧЫ** *и.* Кырыктартмачы, тубалчы. *Шулай да Троицкидагы тормышы бушка узмый: Троицк – күпмилләтле, күп вак кибетле, күп һөнәрчеле (тиречеләр, тегүчеләр, йон-ябага җыючылар, вак тартмачылар), мәдрәсәле һәм, ниһаять, ишанлы шәһәр.* М.Мәһдиев

**ТАРТМАЧЫК** *и.* 1) Кечкенә тартма, котый. *Өстәлгә тартмачыгы белән тоз һәм чәй калагы китереп куйган Нурсинә апа, тукталып, бераз уйланып тора-тора да кабат чоланнарына чыгып китә.* Ф.Яхин. *Фаезнур Дилбәргә кечкенә генә тартмачык сузды.* А.Әхмәтгалиева

2) *бот.* Кайбер үсемлекләрдә орлыкларны каплап яисә үз эченә алып үсә торган савытсыман җимешлек; орлык савыты. *Курак дип мамыклы тартмачыкларны атыйлар.* А.Гыйләҗев. *Аталанганнан соң, ана үсемлекләрдә зиготадан спорофит – озын аякчыкта утыра торган тартмачык ясала.* Биология

**ТА́РТ-ТАРТ** *иярт. к.* **тар-тар**. *[Тартарның] һич кеше белми телен, Тарт-тарт диеп тик ул кычкыра.* М.Гафури

**ТАРТТЫРГЫЧ** *с.* **1.** Тарттыра торган. *Иң элек барлык авыл хуҗалыгы машиналарын да саздан, саламнан, кибәктән арындырырга кирәк, авыл хуҗалыгы машиналарының --- кыскыч һәм тарттыргыч пружиналарны бушайтырга, комбайн һәм тракторларның двигательләренә, су эләкмәсен өчен, тышлык кидерергә кирәк.* Яңа Чишмә хәбәрләре

**2.** *и. мәгъ. к.* **тарткыч** I

**ТАРТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тарту** II (*1, 2, 6 мәгъ.*)

2) Авыр йөк төялгән арба, чана һ.б.ш. нәрсәләрне машинага яки җигүле хайванга тагып, кирәк җиргә шудыру, өстерәү. *Бабайка сугуны син аны ат өстенә менеп, туп арбасы тарттырып манёврга бару дип белдеңме?* М.Гали. *Юллар машина йөрерлек түгел, трактор белән тарттырабыз.* Р.Вәлиев

3) Авыр, озын нәрсәләрне җигүле хайваннан яки машинадан сөйрәтү, өстерәтү. *Болында чүмәлә тарттырган чагым.* Б.Ислам. *Авыл башындагы Хисмәтуллага агач тарттыралар икән, йорт салыргадыр инде?* Ф.Яхин

4) Авыр нәрсәләрне махсус җайланма, машина яисә терлек ярдәмендә тартып чыгару. *Диңгездәге кораб-баржаларны тарттырырдай нык чылбырда утырган бүредән генә түгел, Уссури тайгасы юлбарысы булса да курыкмыйлар бит алар.* А.Хәсәнов

5) Дилбегәне яки тезгенне тартып, атны алгарак күчәргә яки кирәк якка борылырга мәҗбүр итү. *[Әүхәди:] Тарттыр атыңны! – дип, әче тавыш белән кычкырды. Яшь извозчик, атын читкә тартып: – Кая, нишләттегез инде...* К.Тинчурин

6) *к.* **тарту** II (*1, 30–33, 39 мәгъ.*). *Ярма тарттырганда җырлый, ут сүнгәч – бии.* Н.Исәнбәт. *Мольберт, өчаяк, киндер тарттырган рамнар ---*. А.Хәсәнов. *Атамның җәясен тарттыра алу белән, кош өйрәтеп мал туплап, бер яхшы ат алгач та, мин Диләзар мирзага карымта чабам.* Р.Батулла

7) *сөйл.* Кемгәдер тәмәке, папирос һ.б. бирү. – *Ахмый, бер тарттыр әле! – кереп җитмәс борын шулай атакага ыргылыр. Әзерләп куйганнар ди сиңа монда сигарет!* Җ.Юныс

8) Тиешле дәрәҗәдә кысып кую, ныгытып беркетү (гайка, шөреп, яулык тур.). *Кабызу системасына өр-яңа конденсатор куйды, шәмдәге «чаткы аралыгы» дигән нәрсәне бик төгәл үлчәде, контактларны ялтыраганчы чистартты, гайкаларны яхшылап тарттырды.* А.Тимергалин. *Өй ишегеннән, кулларын тастымалга сөртә-сөртә, ак яулыгын башына арттан тарттырып бәйләгән, чиккән алъяпкыч буган, аякларына йон оекбашлар өстеннән күннән теккән чүәкләр кигән бер чибәр генә хатын пәйда булды.* З.Зәйнуллин // Бавыргалык, аркалык ише җигемлек өлешләрен бушаган җиреннән тартып беркетү. *Әхмәт абзый аркалыкны күтәрә, йөгән сабагын тарттыра һәм дилбегәне кулына ала.* М.Мәһдиев

**Тарттыра башлау** Тарттырырга тотыну. *Чөнки невод салынгач та, чите кырыйга килеп җиткәнче, невод арканын вал белән тарттыра башладылар.* Ш.Камал. *Ул бүрәнә тарттыра башлагач, Иблис, кулларын уып, пышылдап кына шигырь сөйләргә тотынды ---*. З.Мәхмүди

**Тарттыра бирү** Бернигә карамый тарттыру. *[Гайфулла:] Тарттыра бир, диләр бит сиңа!* А.Алиш. *Тел – тегермән, тарттыра бирә ул.* Г.Бәширов

**Тарттыра төшү** Бераз тарттыру. *Бауны җиңелчә генә тарттыра төшеп, зур әйләнә ясарга керештем.* Р.Мөхәммәдиев

**Тарттырып бетерү** Бик нык тарттыру; тулысынча тарттыру. – *Болай ял итә-итә эшләсәгез, юллар өзелгәнче дә тарттырып бетермәячәксез! – дип әйткәч, «телсез» ирләр --- Габдерахманга да карап-карап алдылар.* Ф.Яхин. *Башта өләшәбез, берәр атна үтсен, ул арада бөтен кеше аны я Рөстәмбәк, я Яшке тегерменәнә барып тарттырып бетерәчәк.* В.Имамов

**Тарттырып җибәрү** Кинәт тарттыру. *Көз көне мәктәп балалары колхоз бәрәңгесен чыгарырга барганда, «Бе-*

*ларус» кинәт тарттырып җибәрә, һәм арбага төялгән балалар арасыннан Зәбирә егылып төшеп аңын югалта.* Х.Мөдәррисова

**Тарттырып тору** Даими яки әледән-әле тарттыру; әле, хәзер тарттыру. *Бөтен хикмәт шунда: баш түбәсеннән үтәргә тиешле күпсанлы будыргычлы путалар һәрьякка бертигез басым ясап тарттырып торырга тиеш.* К.Җәмит. *Тик моны эшләү җиңел түгел: нидер күкрәкне кыса, яңак сеңерләрен җайсызлап тарттырып тора.* А.Вергазов

**ТАРТТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **тарттыру**. *Монда яңа сугылып, кичә тарттырылган бодай онынннан пешергән кабартма исе – бары тик шул ис кенә килә!* М.Мәһдиев. *Шул казыкларга тарттырылган тимерчыбыкларга йөземнәр бәйләнә икән.* Т.Әйди

**Тарттырыла башлау** Тарттырылырга тотыну. *Инде ашлыкның колхозга калдырылганы да урман артындагы ерак бер ар авылында тарттырыла башлады.* Р.Рахман

**Тарттырылып бетү** Тәмам, бик нык тарттырылу; тулысынча тарттырылу

**Тарттырылып тору** Даими яки әледән-әле тарттырылу; әле, хәзер тарттырылу

**ТАРТУ** I *и. диал.* Кызны ярәшкәч, егет ягыннан кыз өенә бирелә торган акча, ашамлыклар һәм кием-салым. *Иске акча белән йөз тәңкә тарту алып, туй ашына ит-май килешенеп --- эшне бетерделәр.* Ш.Маннур. *Тарту акчалата була. Малайның ата-инәсе кызның ата-инәсенә, шул хәтле акча салам, ди.* Ф.Баязитова

**ТАРТУ** II *ф.* 1) Нәрсәне дә булса көч белән үзеңә таба якынайту; *киресе:* **этәрү**. *Кулы белән Мәүлетдиннең күлмәк якасыннан эләктерде дә үзенә таба тартты ---.* З.Зәйнуллин

2) Берәр нәрсәне якын арага сөйрәп хәрәкәт иттерү. – *Менә бу урындыкка утыр. – Ул миңа да бер камыш кресло тартып куйды.* И.Салахов. *Саура көзге каршына урындык тартып утырды.* М.Хуҗин

3) Билгеле бер якка кучереп кую. *Юрганны аякка тартсаң, баш ачык кала. Башка тартсаң, аяклар – шыр.* Ф.Хөсни. – *Вакыйф! – дидем мин яңадан һәм дустымның өстеннән юрганын тартып төшердем.* А.Гыйләҗев

4) Нәрсәне дә булса сөйрәү, сөйрәп алып бару; нинди дә булса транспорт чараларын сөйрәп йөртү; зур көч белән хәрәкәткә китерү. *Урман юлында нәни арба тартып, чыбык-чабык алып кайтучы берәр карчыкны күрсә, бара торган юлыннан бүленеп, тегенең йөген тартышучы да ул.* Ф.Хөсни. *Гаубица-пушканы чылбырлы тракторлар тартып йөри.* Казан утлары

5) Нинди дә булса якка өстерәү. *Аннары шул теге абый безнең диванның арка сөяп утыра торган өлешен астан эләктерде дә өскә таба тартты.* А.Алиш. *Су хәтта подъезд ишегеннән баскычка таба да үрмәли. Сазлык өйне дә аска таба тарта.* Ватаным Татарстан

6) Күтәреп менгерү, сөйрәп алу, сөйрәп чыгару. *Күнегүләр тәмамлангач, кар белән уынасы яки коедан су тартып коенасы гына кала.* Н.Әхмәдиев

7) Берәр авыр әйберне, йөкне һ.б. сөйри алу, шуңа көч җитү. *Шәйхинең гадәт-холкын, мөмкинлекләрен электән белгәнгә, бу кадәр зур йөкне тартып бара алыр микән, сөрлегеп китмәс микән, дип шикләнеп куйган идем мин.* В.Нуруллин

8) Йолку. *Кишерне тартып чыгару*

9) Кискен өзек-өзек хәрәкәтләр белән селкетү. *Биш яшьлек энесе, җиде яшьлек агасы кайвакытта аны чәченнән тартып елаталар, кайвакытта, сугып китеп, аңар золым итәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Итәктән тарта Вәлия: «Үзем әйтеп бирәм», – ди ---.* Ш.Галиев

10) Сузу, озынайту. *Сагыз тарту*

11) Берәр нәрсәнең тоткасыннан, бавыннан һ.б. җиреннән тотып яки эләктереп, гадәттә үзенә таба кискен хәрәкәт ясау. *Ихсан, дилбегәне тартып, атны юыртуыннан тыйды.* М.Хуҗин. *Көймәче тагын мотор бавын тартты.* З.Хөснияр

12) Берәр корал белән сызып җибәрү, ышкып алу. *[Пычакның] Йөзе начар иде, үтмәс кебек иде. Казанга кайрарга уйлады, анда бушлык иде. Барыбер чарлар дип, чүлмәкнең читенә берничә тартты.* Г.Ибраһимов

13) Аркылы пычкы белән нәрсәне дә булса кискәндә, чиратлашып, коралны үз ягыңа китерү. *Пычкы тартырга хәл калмагач, киселгән утынны өй базына тутырабыз.* Р.Газиз

14) Берәр киемне кигәндә яки салганда, кирәк кадәрле көч кую. *Ул чишенде, Сәрби тутасы пәлтәсе белән бүреген ишек янына элеп куйды, аннары киез итекләрен тартырга булышты.* Р.Вәлиев. *Кулына перчатка тартып кия: җитди операциягә әзерләнә.* М.Маликова

15) Тән әгъзаларын тиз генә җиңелчә кискен хәрәкәт белән читкә алу, бору, күтәрү. *Карлыгач: – Харап булырбыз, өстебезгә килерләр, – дип, көченнән язган гәүдәсен гүя җәберләп читкә таба тартты да өстендәге күлмәген рәтләде, йөзен, башын каплаган чәчләрен тиз генә тарап, кулбашларына төшерде.* Г.Ибраһимов

16) Тән әгъзаларын җыеру, бөрештерү. *Николай, җавап бирмичә, иңбашларын гына тартты.* Ш.Камал

17) Билгеле бер якка борылу, борылып керү; җигелгән яки менелгән хайванны берәр якка бору. *Күк аргамак --- һаман Найман ягына каерды. Азымбай каты итеп өзәңгене кысты, ачулана биреп, яңадан сул якны тартты.* Г.Ибраһимов. *Шуларның, уңгарак каер, сулга тарт, дип кычкырышулары адәм күрмәгән табигать өчен ят ишетелә иде.* З.Мурсиев

18) Берәр якка борылырга тырышу, каеру, омтылу. *Иш ишенә тартыр, ишәк абзарына тартыр.* Мәкаль

19) *физ.* Җисемгә орынмыйча аңа тәэсир итү, үзенә таба хәрәкәт иттерү (магнит һ.б. тур). *Көчле магнит тарткан тимер кебек, Солдат туган җиргә беркә.* З.Насыйбуллин

20) Бау, җеп кебек нәрсәләрне киерү, туп-туры торырлык итеп сузып, башбашларыннан беркетү, тарттырып кую. *Эшче батальоннар шәһәр тирәсенә окоплар казыйлар, баганаларга чәнечкеле тимерчыбыклар тарталар.* И.Гази

21) Каеш, бау кебек нәрсәләрне кысып торырлык итеп бәйләү. *Сылап, сыйпап, ялыннан, тамак астыннан иркәләп, аның башына озын, калын*

*тезгенле каеш нуктаны кидерделәр, ике катлаулы сагалдырыкны каты тартып бәйләделәр.* Г.Ибраһимов. *Киң күкрәге белән, тартып бәйләнгән каеш аркалыкка ята биреп алга таба иелә төшә дә, ике тәртәне зур куллары белән ныклап кысып тотып алып, арбаны алга өстери башлый.* З.Зәйнуллин

22) Билгә буу. *Син, Шинелең киеп, каеш тартып, Сафка бастың мине сакларга.* Ә.Ерикәй

23) Тигез итеп тасма, ука кебек нәрсәләрне беркетеп тегү. *Читенә кама тарткан камзул шактый салмак була.* И.Рәмиев

24) Һәртөрле яссы яки тасма сыман әйберләрне махсус кысага яки берәр форма, калып өстенә киерү. *Калын шин тартып, болтлар белән ныгытылган һәм яшелгә буяган тимер ишек.* А.Тимергалин. *Әҗерен көтә һаман күңелемнең Ап-ак киндер тарткан киергесе. Кара буяу сылап үтә җанга, Әле берсе очрап, әле берсе...* Л.Шагыйрьҗан

25) Бер чыбыкка, җепкә тезелгән нәрсәләрне күчерү, күчереп кую; уңгасулга йөртү. *Тора башлаган беренче көннәрендә аларның бөтен эше – ашауэчү, йоклау, йокыдан торып янә ашау, намаз уку һәм тәсбих тарту гына иде.* М.Галәү. *Күтәреп эшлисе эш түгел, чут төймәсе тартып, идарәдә генә утырасы.* В.Нуруллин

26) Каплау яки ачу максаты белән аска, уңга яки сулга өстерәү. *Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч буган оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самавыр артынарак килеп утырды.* Ә.Еники. *Сөем тутай кояш нурларын каплап торучы чаршауны тартты, бүлмәгә шат яктылык ургылып керде.* Р.Батулла

27) Күпер, басма кебек озынча һәм туры корылмаларны төзү, ясау. *Тегермән янындагы ике текә яр арасына асылмалы күпер тартылган.* Г.Гыйльманов

28) Билгеле бер ноктадан икенче ноктага кадәр үткәрү, салу, төзү, сузу (элемтә, коммуникацияләр һ.б.ш. тур.). *Аның каравы Күктәкәгә газ тарттык.* Ә.Исхаков

29) Суырып эчкә кертү; эчү. *Хәзрәт, төкереген авызының эченәрәк тартып: – Сөбханалла, күз тимәсен, – ди.* Ф.Әмирхан

30) Тәмәке, махорка кебек никотинлы матдәләрнең төтенен махсус җайланмалар ярдәме белән бер-бер артлы эчкә, үпкәгә суыру. *Барысына түзәргә була, тик тартасы килүгә чыдар әмәл юк.* Ф.Хуҗин. *– Төреп тартыйк! – ди Сәлам абзый, минем тәмәке тартмаучы икәнемне белсә дә, гадәт өчен.* Ф.Яхин

31) Курай, сорнай, флейта кебек тынлы музыка коралларында уйнау. *Әхмәдулла, тәрәзә янына утырып, курай тарта.* А.Гыйләҗев. *– Тарт сорнаең, Сабирҗан! – дип сөрән салды Тархан.* Р.Батулла

32) Кубызда, скрипка һ.б. кыллы музыка коралларында уйнау. *Думбралар чиертеп, кубызлар тартып, курайлар уйнап, шатлык белән кайтып керделәр.* Әкият. *Карт, уйнавыннан туктап: – Син скрипка тарта беләсеңме? – дип сорый.* Әкият

33) Гармун һ.б. күрекле музыка коралларында уйнау. *Авылда кемдер өздереп-өздереп тальян тартты, ераклашып барган тальян тавышы белән ул тавыш бергә кушылып, тыныч замандагы Сабантуйны хәтерләтте.* М.Мәһдиев. *Минем ишеләрне кочак җәеп каршы алачаклар: барып, аккордеонны гына тартып күрсәтәсе...* М.Маликова

34) Ашлыкны махсус җайланмада, гадәттә ике махсус таш арасында ваклап, ярма яки он итеп чыгару. *Ул тегермәннәрдә игенне тартып он иткәннәр, кабыгын суыртып, ярма ясаганнар.* З.Зәйнуллин. *Тегермән аңа бер күәс чиләге он тартып биргән.* Г.Гыйльманов

35) Нәрсәне дә булса махсус механизмнар ярдәмендә ваклап, он, порошок хәленә китерү. *1911–1913 елларда Водянск шәһәрлеге җирләреннән якындагы сөяк тарту заводы өчен сөякләр казып чыгарыла.* А.Тимергалин

36) Азык продуктларын махсус җайланма аша үткәреп ваклау. *Малайлар тормыйлар да тормыйлар, итемне дә тартып бирмиләр.* Ф.Яхин

37) *сир.* Гадәттә кул сепаратында сөт аерту. *[Сөтне] Фәтхиләргә барып тарттым.* М.Фәйзи

38) Дым, пар, төтенле яки салкынча һава үтеп кереп таралу. *Кояш инде баеган. Бөтен Ык буен су салкыны тарткан.* Г.Галиев. *Төнге салкыннан әйберләр дым тарткан.* Р.Хәбибуллина

39) Бизәнү өчен, махсус буягыч белән кашка, күз тирәсенә сызу. *Урам як ишегенең баскычыннан төшкәндә, присяжныйлардан берсе – күзенә сөрмә тарткан татар агае – кинәт тукталып калды да баскыч төбендә сөйләшеп торучы бер төркем кешенең сүзләренә колак салды.* М.Галәү

40) *к.* **тартышу** (*8 мәгъ.*). *Сул күземнең почмагы тарта, егетләр, Нәсимә кыздырмаса гына ярар иде.* Ш.Камал. *Таза егет --- кечерәеп кенә агач арасына яшеренгән каенда да күз кабагы тарткан кадәре дә селкенү дә, хәрәкәтләнү дә күрә алмады.* Г.Исхакый

41) Тоташ каплап алу. *Яман елгага җитүләрен генә көткән: бүген тагын күк йөзен болыт тартты, яңгыр, утырып, үзенә бер күңелсез көй белән яварга тотынды.* Җ.Рәхимов

42) *күч.* Сузып-сузып көйләү. *Сәгыйдә апа --- карт белән Газизәнең озак кайтмауларына эче пошканнан, ишетелер-ишетелмәс кенә, авыз эченнән ниндидер бер көй тартып моңая иде.* Ш.Камал

43) *күч.* Каты итеп сугу; манчу, кундыру, салу. *Берне тартыр идем инде үзеңә!* Р.Сәгъди

44) *күч.* Берәр хис кичерү, берәр рухи халәттә булу; чигү. *Вакыйган, быел болай да күп хәсрәт тарткан бу кечкенә гаиләнең тагын аерылып таралуы, хосусан, ана белән кыз өчен түзүе читен һәм эч өзәрлек бер хәл иде.* Ш.Камал

45) *күч.* Игътибарны җәлеп итү, үзенә багындыру, карату. *Хәятның матур йөзе бөтен узып баручыларның күзләрен үз төркемнәренә тарта иде.* Ф.Әмирхан. *Чикерткә сикерүне шунда туктатты һәм кунакларны тагын үзенә тартты.* А.Алиш

46) *куч.* Үзенә таба барырга мәҗбүр итү (берәр яхшы, кызыклы һ.б.ш. ягы булган урыннар тур.); сагындыру, юксындыру. *Без белгән сулар эчендә моның чикле балыклысы булмаганга, күңел, һичбер куркуга карамыйча, моңа тартты.* Г.Ибраһимов. *Нинди магнит тарта аларны шәһәргә?..* В.Нуруллин

47) *куч.* Беленмәгән эчке көч, серле бәйләнешләре белән үзенә китерү (туган җир, берәр чит-ят, ерак яки мистик урын тур.). *Туган туфрак дигән нәрсә дә бар бит әле, чит җирләрдә йөргәндә, ул гел искә төшеп, үзенә тарта, төшләргә кереп йөдәтә.* Ф.Хуҗин. *Сөембикә манарасы янындагы бакчага мине нинди көчләр тартып китергәндер, анысын әйтә алмыйм.* А.Тимергалин

48) *куч.* Билгеле бер халәткә якынаеп үзгәрү, авышу. *Көзге пычраклар бетеп, көннәр салкынга тарта башлаган иде инде.* Г.Галиев. *Көзгә тарткан җәйге иртә барыбер дә чирканыч суык икән.* Ә.Әминов

49) *куч.* Сокландырып, кызыктырып, кемгә яки нәрсәгә дә булса якынаерга, кайдадыр булырга мәҗбүр итү. *Рус җәмгыятенең күңелле тормышы аның яшь йөрәген үзенә тарта да, ул Мясниковлар һәм башка кайбер рус гаиләләренең күңелле вечерларында төнге сәгать өчкә кадәр танцевать итә ала иде.* Ф.Әмирхан. *Аңлавымча, Азатны киңлек-иркенлек, хөр табигать үзенә тарта һәм, иң мөһиме, аңар адәми зат арасында элек-электән очраштыра торган сәер кешеләр – илгизәрләр каны тынгы бирми, күңелен кытыклап, юлга, сәфәргә офык артына әйдәкләп тора иде.* А.Тимергалин

50) *куч.* Үтенеп, үгетләп яки мәҗбүр итеп берәр җиргә китерү, берәр оешмага кертү һ.б. *Балалары карчыкны калага тартып караганнар иде дә каравын, ләкин ул гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде.* Ә.Еники

51) *куч.* Берәр эш өчен туплау, оештыру; нindидер эшкә, процесска җәлеп итү; агитацияләү. *Сәйфинең җыр яратуын һәм җырларга дәрте барлыгын белгәч, матур гына җырлаганын да ишеткәч, аны ул сәхнә тирәсенә тартырга тырышты.* А.Алиш. *Сездәй галимнәрне бүгеннән фәнне җитәкләү эшенә тартмасак, иртәгә соң булачак!..* Ф.Яхин

52) *куч.* Эшләрлек булу, хәленнән килү, булдыру. --- *колхозны тартырлык, күтәрерлек элекке персидәтел Гапсаттар исән-имин, күкрәгенә орден-медальләр тагып, сугыштан кайтты* ---. Р.Хәбибуллина. *Дөрес, Нурижан да тарта алыр иде бу вазифаны, ләкин ул – менә дигән инженер, рационализатор, уйлап табучы.* З.Мурсиев

53) *куч.* Әхлакый, рухи һ.б. яктан үгетләү, үрнәк булу, этәргеч, стимул бирү. *Теләгән үргә тарта, языгы түнгә тарта.* Мәкаль

54) *куч.* Билгеле карашларны яклау. *Их, әти, һаман искелеккә тартасың.* З.Мурсиев

55) *куч.* Фикер, әңгәмә юнәлешен, асылын, характерын билгеле бер якка үзгәртү. *Җәләл гел уенга тартып сөйләшә.* Г.Ибраһимов. *– Кем беренче килә? – дип, бәхәскә тарта бер малай.* Р.Батулла

56) Китереп чыгару, барлыкка килүгә сәбәп булу. *Хәмер сүзне тарта бит ул, ни турында гына сайрашмадылар: дәүләт эшләре дә калмады, орыш-сугыш та, гыйшык-мыйшык хәлләре дә...* М.Әмирханов

57) *куч.* Берәр кемгә, нәрсәгә охшаш, тартым булу. *Кадрлар бүлеге мөдире – Бикбау фамилияле кеше – карап торышка инде күптәнге пенсионер, әүвәлге номенклатура әһеленә дә тарткан* ---. А.Тимергалин. *Тавышың Фәридә Кудашеванықына тарткан икән.* Р.Сәгъди

58) *куч.* Чигендерү, тотып калу, тыю. *Нәрсәне, тарт, ди икән бу? Нәфсеңне тарт, ди микән?* М.Гафури

59) *куч.* Вакытны озайту, сузу. *Шулай да, тагы бер генә колода, тагы бер генә колода, дип тарта-тарта, сәгать икегәчә маташтылар да тарала башладылар.* Г.Ибраһимов

60) Үлчәүдә билгеле бер авырлыкта булу. *Кайткач, бизмәнгә салып карадык: дүрт кадакка якын тартты [бәрәңге].* М.Кәрим

61) *иск.* Берәр җайланмада әйбернең авырлыгын үлчәү. *Элек чүпрәкнең чамасын тартты, аннан соң табакның бер ягына ике кадаклы герне куйды да, бер алуда ук, һичбер мыскалга да ялгышмастан, соскы белән кара онны китереп салды.* Г.Ибраһимов

62) *куч.* Нәрсәнең дә булса бәясе билгеле бер суммалык булу; шул суммага сатып алырлык яки җибәрерлек тору. *Кайчакларда бу сумма мең сумга да тарта.* Ф.Хуҗи

63) *куч.* Билгеле нәрсә бәрабәренә тору, билгеле хакка төшү. *Аеруча вәхшилек белән кеше үтерү, җитмәсә, авырлы хатынны бит әле, бу беләсеңме күпмегә тарта?* З.Мурсиев

◊ **Тарта торгач он булыр** Тырышып, түземлек белән эшләнгән эшнең нәтиҗәсе булмый калмас. *Айдар, әкренләп аның [хатынының] холкына да ияләшермен, тарта торгач он булыр, дип карый.* Ф.Хөсни. *– Нишләп? – диде Өлфәт. – Тарта торгач он булыр әле. Әллә кая китмәс...* А.Тимергалин. **Тартып алу** 1) Көч, хәйлә һәм башка шундый юллар белән кеше әйберенә хуҗа булу. *Дөрес, бу урман хәзер безнеке түгел, аны әллә ничек итеп безнең кулдан бер бай тартып алган, хәзер безгә аннан бер чыбыркы сабы да алырга ярамый!* Г.Ибраһимов. *Йортын тартып алганга эче поша булыр.* А.Алиш; 2) Юк итү. *Әйтте аңа Зөләйха: «Мин йоклый идем, Төшемдә мин бик зифа бер сурәт күрдем ---. Гакылымны, сабырымны тартып алды, – Күңлем аны бертуктаусыз тели имди».* Кол Гали. **Тартып чыгару** Берәр авыр хәлдән коткару, йолып алу. *Адвокат сора, җәлләмә акчаңны, яхшы адвокат ничек тә моннан тартып чыгарыр!* Р.Хәбибуллина

**Тарта бару** Торган саен ныграк тарту. *Төннең гомере кыскара, Көн яктысы арта бара. Әкрен-әкрен, сиздермичә, Көнне язга тарта бара...* Р.Вәлиева. *Шуның өстенә һәр сүзе, һәр яңа фикере белән әңгәмәдәшләрен үзенә якынайта, тарта бара иде сыман ул.* Р.Мөхәммәдиев

**Тарта башлау** Тартырга тотыну. *Камалетдин шунда ук Гыймадиның кулындагы арканга ябышты һәм тарта башлады.* Ф.Яхин. *Көн инде, күзләрен йомып, өстенә юрганын тарта башлаган иде.* М.Яһудин

**Тарта бирү** Бернигә карамый тарту. *Ләкин җегет әйтерсең аркага ябышып үскән иде, ат сикеренгән саен авызлыкны тарта бирде.* Г.Ибраһимов. *Әмма шушы муллык, иркенлек аны һаман-һаман үзенә таба тарта бирде.* Н.Акмал

**Тарта тору** Өлегә тарту; даими тарту; әледән-әле тарту. *Җабирны әледән-әле югарыга тарта тордылар: әүвәле партия укуларына җибәрделәр.* Ф.Яхин. *Фәгыйлә апа чабуыннан тарта торгач, Сәмигулла урыныннан торды да салкын суга башы белән чумарга әзерләнгән кешедәй, ух, дип куйды.* Н.Кәримова

**Тарта төшү** Бераз тарту; тагын да ныграк тарту. *Корыклы казакъ сабырсыз айгырын тарта төшеп, көнчыгыш ягына карап: «--- әнә шул Яман Чүл дигән җәйләүдә Арысланбай булыр!»* Г.Ибраһимов. *– Яле, менә болайрак тот, чабып китергәндә, чак кына үзеңә тарта төш, – дип, киңәшләрен бирде.* А.Тимергалин

**Тартып алу** Бераз тарту. *Әгәр дә инде тәмәке тартып алырга тәнәфес бирсәләр.* З.Мурсиев

**Тартып бетерү** Бөтенләй, тулысынча тарту; бик нык тарту. *Тәмәкене тартып бетереп, төпчеген парашага ташладым да, чишенеп, караватка яттым: бер рәхәтләнеп йоклыйм әле.* И.Салахов. *«Җитте, үзеңә тиешлесен тартып бетердең!» – дип, беравыздан кычкыра иптәшләрем.* Ф.Хуҗин

**Тартып җибәрү** Кинәт кенә тарту. *Шул чак өстәл өстенә җәйгән ашъяулыкны кулы белән ялгыш тартып җибәрде дә, чокыр идәнгә төшеп челпәрәмә килде.* М.Хуҗин. *Кызылга буялган тимер боҗраны тартып җибәрүем булды... нәрсәгәдер дөпелдәп бәрелдем.* М.Юныс

**Тартып кую** Тиз генә тарту; алдан тарту. *Утрауда эшләр әнә шулай эзгә төшә башлады. Таганнан соң, волейбол уйнарга баганалар утыртып, ятьмә тартып куйдылар.* Ф.Яруллин. *Тезгенне тиз генә тартып кую аркасында, җирән кашка тукталып калды.* Н.Яһудин

**Тартып тору** Даими яки әледән-әле тарту; әле, хәзер тарту. *Урам чатларында татарча язылган бик зур афишалар ялт итеп узган-барганның дикъкатен тартып тордылар.* Ш.Камал. *Эчеңдә күп серләр саклап, сихрилегең белән үзеңә тартып тор!..* А.Хәсәнов

**Тартып утыру** *сөйл. к.* **тартып тору**. *Ул өй ишеген ачып кергәндә, Бибиәсма сәке уртасында намазлыгын җәеп, оеп, дисбе тартып утыра иде.* Д.Каюмова

**Тартып яту** *сөйл. к.* **тартып тору**. *Иртә чыга торган үләннәр буй тартып ята.* З.Мурсиев

**ТАРТЫК** *с. лингв.* **1.** Сөйләү аппаратында һава агымының тоткарлык аша үтү нәтиҗәсе буларак ясалган (аваз тур.). *Кайсыбер тартык авазларның әйтелешендә дә аермалыклар бар.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ.* Шул рәвешле ясалган аваз. *Андый очраклардан исемнәр ясауда кулланылган яңгырау тартыкларның саңгыраулаштырылуын башкача аңлатып булмый.* М.Әхмәтҗанов. *Кече тел тартыгына тәмамланган сүзләрне язуда, аларга кушымча ялгауда да төрлелек еш күзәтелә.* Р.Абдуллина

**ТАРТЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тарту** II. *Аннары... аннары малайларның игътибары буа уртасында калган утраугa тартылырга тиеш иде...* А.Тимергалин. *Басуда игеннәр җыелып беткәч, яңа ашлыктан тартылган оннан умач пешергәннәр борынгылар.* Г.Гыйльманов

2) Тартырга туры килү. *Тартасы тартылган, эчәсе эчелгән, күрәсең.* И.Диндаров

3) Кискен хәрәкәткә килү. *Әмма кыз кинәт тартылды, һәм аның җиңе Баламир углан кулында калды.* М.Хәбибуллин // Кинәт алга кузгалып яки кинәт борылып кискен хәрәкәт ясау (җигүле ат һ.б. тур.). *Ат тагын тынычсызлана, тартыла, чыгымлый башлады.* Р.Батулла

4) Киерелү. *Соңгы чиккә кадәр тартылган, өзелергә торган скрипкә кыллары елый.* А.Шамов

5) Гәүдә, аяк-кулны сузу, язу; киерелү. *Иртә белән йокыдан уянуга, салмак кына сузылырга, тартылырга кирәк. Аннан бераз йөгереп алу бик файдалы.* Авыл утлары

6) Ычкынырга тырышу, ычкынам дип талпыну. *Ул корбанлык тәкә сыман акыра, җан ачысы белән тыпырчына, тибенә, тартыла, ләкин ычкына алмый иде.* М.Галәү. *Ул ычкынмакчы булып тартыла, әмма аркан өзелми, өчтән үрелгән юкә муенчак та салынмый, күп тырыша торгач, казык суырылып чыга.* М.Хуҗин

7) Торган урыннан тиз генә читкә китү, тайпылу, тайпылып кую. *Шүрәледән куркып, ул тартыла, Уйлый, ахры, аннан качарга.* С.Хәким. *Боларны искә алу Розаның күңелен тынычландырды, ул инде читкәрәк тартылды.* Ф.Яхин

8) Билгеле бер тарафка авышу, шул яккарак юнәлешне үзгәртү. *Ут белән каплау группасы, маңгайдан барып, сазлык як флангкарак тартылырга һәм шунда оборонага урнашырга тиеш.* Ф.Кәрим. *Менә мин кайда икәнмен. Димәк, төньяккарак тартылганмын.* И.Хуҗин

9) Сузылып озынаю, озынча форма алу. *Ат, тартылып, далага очты*

10) Сузылу, вакытны алу. *Бу эшләр күпмегә тартылгандыр – анысын әйтүе кыен.* А.Тимергалин. *Сугыш бик хәтәр булды, озакка тартылды.* Р.Батулла

11) Билгеле бер характер, юнәлеш алу. *Ләкин кымыз эчеп кәеф күтәрелгәнгә, сүз болардан уен-көлкегә тартылса, һәммәсе дә шат булачаклар иде.* Г.Ибраһимов

12) Ябыгып китү, какчалану. *Сукыр Гыйсмәт карт тагын да тартылган, ябыккан иде.* Ф.Яхин

13) Буйга үсеп китү. *Сугышка кадәр әле кечкенә булган, ә күренми торган берничә елда буйга ярыйсы ук тартылган үсмер отпуск ялының берничә көнендә миңа нык ияләнгән иде, шуңа да аерылышу аның өчен аеруча кыен, менә-менә кычкырып елап җибәрер төсле.* Ф.Хуҗин. *Гыйльметдин егет булгач та буйга әллә ни тартылмады, курач көе калды ---.* М.Кәрим

14) Пәрдә, чаршау һ.б.ш. нәрсәләр белән каплану, өртелү; яры, томан һ.б. пәйда булу. *Хәзер инде җир өстенә караңгылык пәрдәсе тартылды.* С.Поварисов

15) Билгеле бер юнәлешкә омтылу, сузылу, үрелү. *Чәчәкләр язларга, кояшка тартыла?* Г.Гыйльметдинова. *Каен ботаклары җиргә таба тартылган*

16) *к.* **тартыну**

17) *күч.* Эчке бер тойгы белән омтылу, якын күрү. *Фәләхләр мәктәбендә аңардан да сылурак, матурраклар бар иде барын, ләкин аның күңеле нигәдер гел әнә шул тыйнак һәм тырыш Розага тартылды, аны якын итте.* В.Нуруллин. *Мин беркайчан да байлыкка, тәхеткә тартылган кешеләрне аңламадым.* А.Нәҗми

18) *күч.* Киеренкеләнү. *Күңел кылы соңгы чиккә җитеп, Соңгы көрчегенә тартылган.* Г.Гыйльманов

19) *күч.* Каплану, каплап китү. *[Гыймадиның] элекке көр, ачык чырайлы йөзенә ваем күләгәсе тартылды.* К.Нәҗми

**Тартыла бару** Торган саен тагын да тартылу. *Гадел Сезгә көннән-көн ныграк тартыла бара.* Г.Гыйльманов. *Без дә акрынлап тартыла бардык.* Ф.Яхин

**Тартыла башлау** Тартылырга тотыну. *Караборын Әйдүкнең арбага утырып китәсен күргәч, аңарга табан тартыла башлады.* Һ.Такташ. *Илнур бу юлы күлмәкне эләктереп алды һәм боз өстенә менмәкче булып тартыла башлады.* Ф.Садриев

**Тартыла бирү** Бераз тартылу. *Байчобар түзмәде, тартыла биреп, Алтын Күл буеннан киң далага җегетне алып очты.* Г.Ибраһимов

**Тартыла тору** Әлегә тартылу; әледән-әле тартылу; шактый вакыт тартылу. *Моның әҗәле җитмәгәнгә каршы, ау иске икән: күп тартыла торгач, ауны өзде дә котылды*. Г.Тукай

**Тартыла төшү** Бераз тартылу. *Гайникамал апасы, бик изге эшкә керешкәндәй, китапны ачты да лампа яктысына тартыла төшеп укый башлады.* М.Хәсәнов. *Приск --- атын куалабрак алып китте, җайдак ат, аз гына тартыла төшеп, бер җайдан юрта башлады.* М.Хәбибуллин

**Тартылып алу** Беразга тартылу

**Тартылып бетү** Тәмам, тулысынча тартылу; бик нык тартылу. *Нервыларым тартылып бетте, өзелә хәзер синең аркада!* Н.Кәримова

**Тартылып китү** Кинәт тартылу. *Шул чакта ялгыш тартылып киткән курок капсульгә бәрде.* Г.Гобәй. *Яки менә бая, үгез тартылып киткәндә, берәребезнең чана табаны астында кысылып калуы мөмкин түгел идемени?* В.Нуруллин

**Тартылып кую** Кинәт тартылу. *Мөхәммәдьяр картның йөрәк тамырлары, өзелердәй булып, тагын бер мәртәбә тартылып куйды.* Г.Гыйльманов

**Тартылып тору** Әле, хәзер тартылу; даими яки әледән-әле тартылу. *Уң якта бер авыру яткан; өйне урталый бүлгән чаршау аз гына тартылып тора; сул якта иске генә ак күлмәкле, башында яулыклы бер хатын иске ямап утыра.* Г.Исхакый. *Әйтерсең гомер буе, нииндидер элмәккә эләгеп, пружина кебек тартылып торганмын да, менә хәзер авылга кайткач, бар җепләр өзелгән, юкка чыккан.* А.Әхмәтгалиева

**ТАРТЫМ** I *с.* Берәр нәрсәгә яки затка охшаш, шуны хәтерләткән. *Ә чаялыгы белән ул малайларга да тартым, ахрысы.* А.Тимергалин. *Озын, төз буйлы, якты һәм кыю йөзле, башкортларныкына тартым тере кара күзле егет сокланырлык иде шул.* Г.Әпсәләмов

**ТАРТЫМ** II *и.* 1) *сөйл.* Нинди дә булса тартып баручы көч тарта алырлык йөк, авырлык һ.б.ш. күләме. *Ул [Шәңгәрәй] элекке көннән үк ат тартымы ике йөк [салам] китереп аударды.* Г.Ибраһимов

2) Нәрсәнең дә булса бер тапкыр тартып чыгарылган күләме. *Бер тартымга өч-дүрт центнер балык эләгү*

**ТАРТЫМ** III *и. лингв.* Төрки телләрдә предметның нинди дә булса затка (яки икенче бер предметка) караганлыгын белдерә торган категория. *Рус һәм гарәп телләрендә, мәсәлән, җенес (род) категориясе бар, ә төрки телләрдә исемгә тартым категориясе үзенчәлекле.* Ф.Хисамова. *Тартым кушымчасы ялганганда, бу сүзләрнең орфографиясе бертөрле генә түгел ---.* Р.Абдуллина

**ТАРТЫМЛЫ** I *с. ялг. к.* **тартым** I. *XIV гасырда А.Рублёв иконаларындагы хатын-кыз сурәтләре Аурупа сәнгатеннән читләшкән стильне тәшкил итсә, XV гасырда Флоренция рәссамы А.Боттичелли якын киләчәктә урнашачак реализмга тартымлы стильдә иҗат итә.* К.Гыйззәтов

**ТАРТЫМЛЫ** II *с. грам.* Тартым категориясе булган; тартым белән төрләнгән. *Татар телендә сөйләм вакытыннан элек булган процессны белдерә торган тартымлы үткән заман сыйфат фигыль белән «бар» сүзеннән ясалган яисә кабатлау юлы белән төзелгән үзенчәлекле хәбәр конструкцияләре кулланыла.* Р.Юсупов

**ТАРТЫМЛЫК** I *и.* Охшашлык, тартым булу. *Шунлыктан, бу сүзләрне сөйләгәндә, аның күңелендә аз гына да шаяруга тартымлык юк, бәлки Хөсниҗамалга төбәлгән ачы мыскыллау гына бар иде.* Ш.Камал. *Анда М.Әмирнең «Агыйдел»ендәге Артыкбикә чалымнары да, Ә.Еникинең «Туган туфрак» хикәясендәге Кларага тартымлык та бар кебек.* Ф.Хатипов

**ТАРТЫМЛЫК** II *с.* Чамалык; билгеле нәрсә чамасында булган; якынча билгеле күләмдәге. *Ике бәртәс, өчәр кадакка тартымлык ике чуртан, дүртбиш данә кылчак, хәтта уч калынлыгы зурлыктагы бер карабалык Сөләйманга ияреп барган Әсфәндиярның брижҗин капчыгында ара-тирә шапырынгалап куя иде инде.* Ә.Гаффар

**ТАРТЫМСЫЗ** *с. грам.* Тартым категориясе булмаган; тартым белән төрләнмәгән. *Төрләнешнең гадәттә ике төре аерып карала: тартымсыз төрләнеш һәм тартымлы төрләнеш.* Ф.Хисамова. *Ләкин мәктәп грамматикасында кабул ителгән төрләнешне янәшә куеп карасак, без тартымсыз исемнәрнең килеш кушымчыларында аерма булуын күрербез.* Ш.Асылгәрәев

**ТАРТЫНКЫ** *с.* 1) *иск.* Тартык. *«Имла нигезләре»ндә Г.Нугайбәк, татар әдәби телендә калынлы-нечкәле биш пар сузынкы (сузык), 22 пар тартынкы (тартык) аваз бар, дип күрсәтә.* Фән һәм тел

2) *сөйл.* Бик нык тартылган; өзеләмөзеләм дип тора торган. *Гел тартынкы мускул ял итә алмый.* Г.Хөсәенов

3) *күч.* Киеренке булган. *Моңарчы чүкердәшеп яшәгән ир белән хатын арасында кинәт мондый тартынкы сүзсезлек урнашып калуы аларның үзләре өчен дә читен ---.* Ф.Хөсни

**ТАРТЫНКЫЛЫК** *и.* 1) Тартынкы булу. *Ә мускул тартынкылыгы нервы тартынкылыгыннан килә.* Г.Хөсәенов

2) *күч.* Киеренкелек, үзара ризасызлык. *Мәҗлестә хөкем сөргән бу тартынкылыкны чамалап, Ахунҗанов сиздермичә генә чыгып сызу ягын карады.* Ф.Хөсни

**ТАРТЫНКЫРА́У** *ф.* Бераз тартыну, азрак уңайсызлану, оялу

**Тартынкырап алу** Бераз тартынкырау

**Тартынкырап тору** Әле, хәзер тартынкырау; даими, әледән-әле тартынкырау. *Без күңелсез бер хәлдә тартынкырап торган идек тә, өй хуҗасы, моны сизеп, борынгы танышларча мөгамәлә итә башлады.* М.Гафури

**Тартынкырый төшү** Берникадәр тартынкырау

**ТАРТЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **тарту** II

2) Оялу, оятсыну; кыяр-кыймас хәлдә булу. *Ул бераз тартынып, бераз кыюсызлык белән башласа да, тиз ачылды: сүзгә күп колак салмыйча, бәлешләрне, салкын каз итләрен туктаусыз йота башлады.* Г.Ибраһимов. *Ильяс күршеләрне биюгә чакырып карый, ләкин барысы да тартыналар һәм биючедән читкәрәк качалар.* З.Хәким

3) Баш тарту, ваз кичү. *Әлегә, шигырь язмый торганда, җырлаудан тартынмыйм.* Г.Тукай. *Син үз вазифаңны үтәүдән нинди авыр, нинди ачы булса да тартынма!* Г.Исхакый

**Тартына башлау** Тартынырга тотыну. *Болай да, сугыш чыкканнан бирле, Локман авылдашларының йөзенә күтәрелеп караудан тартына башлады.* Ф.Яруллин

**Тартына килү** Күптәннән бирле тартыну. *Җенси шөгыль хакында, тыелган нәрсә кебек, ачыктан-ачык сөйләшергә тартына килдек, хәтта әдәпсезлеккә санадык аны.* Г.Хөсәенов

**Тартына төшү** Бераз тартыну. *Үзенең эчкерсез сүзләреннән уңайсызланып куйдымы, беркадәр тартына төшеп елмаеп җибәрде ул шунда.* Р.Мөхәммәдиев. *Гөлбәдәр, бераз тартына төшеп, яшь белән җепшекләнгән озын керфекләрен түбән иде ---.* Н.Яһудин

**Тартынып тору** Әле тартыну. *Тегесе тартыныбрак торса да, әз генә үгетләгәч, бүтәннәр күз ачып йомган арада, ипине кечкенә ябык куллары белән эләктереп тә алды.* Ә.Баян. – *Йомышыгыз төшкәндә тартынып тормагыз, апа, – диде ул, соңгы сүзе итеп.* Н.Әхмәдиев

**ТАРТЫНУЛЫ** *с.* Тартыну сизелеп, күренеп торган. *Йөзендә – тартынулы елмаю, озын кара керфекләре коңгырт төстәге керсез саф күзләрен күләгәләп, тетрәнгәләп куя.* Г.Ахунов

**ТАРТЫНУСЫЗ** *с.* **1.** Тартыну сизелмәгән, тәкәллефсез. *Дус-иш яки таныш-белешләрнең үзара иркен, тартынусыз сөйләшүе ул.* Р.Абдуллина

**2.** *рәв. мәгъ.* Тартынмыйча, оялмыйча. *Олылар бернинди тартынусыз ишегалдына кереп, өйдәге бәхәсне тыңлап торалар иде.* М.Галәү. *Яшьләр, һич тартынусыз, ханымга тагын бер сынаулы караш ташладылар.* Ә.Еники

**ТАРТЫНУЧАН** *с.* Оялчан, юаш; тартына, ояла, уңайсызлана торган. --- *Үзен һич тә күпертергә, күрсәтергә яратмаган, тартынучан, оялчан табигатьле бу кеше шулай шауламыйча гына, әкрен-әкрен үз эшен эшләп бара иде.* Г.Әпсәләмов. *Хәер, тартынучан димәс идем мин аны: күргән-кичергәннәрен бер дә иренмичә сөйли, кәефе килсә, берәр озын көйгә карлыга төшкән тавышы белән сузып та җибәрә.* Ә.Еники

**ТАРТЫНУЧАНЛЫК** *и.* Оялчанлык, тартыну, тартынып тору сыйфаты. *[Егетнең] Элекке тартынучанлыгы беткән.* Г.Әпсәләмов

**ТАРТЫ́П-СУЗЫП** *рәв.* 1) Төрлечә тартып, төрле яктан тарткалап. *Садрый Мәрьямне тартып-сузып ишектән чыгара.* Ш.Камал

2) Тарткалап, киңәйткәләп, җәеп, билгеле бер формага кертеп. *Ясалма кәрәзләрне бал салырга яраклы итеп тартып-сузып эшлисе бар.* А.Алиш

3) *күч.* Җитеп бетмәгән, тулып бетмәгән нәрсәне дә булса, бер чарасын табып җиткереп, тутырып һ.б.ш. *[Нуретдин:] Икесеннән, тартып-сузып, бер киемгә аслык чыкса чыгар.* К.Тинчурин

4) *күч.* Шартлы рәвештә генә, тулысынча туры килмәвен белә торып. *Ук белән җәяне, тимерче күреге, сыбызгы, сал һәм көймә, буяу, көзге кебек нәрсәләрне, тартып-сузып булса да, табигатьтән алынган идеяләр рәтенә кертергә мөмкин.* А.Тимергалин

5) *күч.* Булганнан артыграк итеп күрсәтеп, карап, санап һ.б.ш. *Димәк, тартып-сузып санаганда, дүрт-биш ел гомерең калган була.* Ш.Камал

6) *күч.* Тырыша-тырмаша, көчкә, көчәнеп. *Сугышның беренче елларында ирсез калып, тартып-сузып үстергән бердәнбер улыннан да язган Гайнисә түти.* М.Хәсәнов

**ТАРТЫШ** *и.* 1) Тарту II (*1–9 мәгъ.*) күренеше. *Колаклардан, чәчләрдән тартыш, изүләрдән, якалардан, итәкләрдән йолкыш.* Ә.Баян

2) Бер-береңне тартып, якалашып сугышу. *Тартышка китсә, көч белән алдыра алмаячагын үзе дә сизенде булса кирәк (шаярып көрәшеп уйнаган вакытларда гел мин ега идем аны), өйалдында сөйләшкәндә, шактый нык әтәчләнсә дә, теге кичне Рәдиф миңа комачаулап, бәйләнеп йөрмәде.* В.Нуруллин

3) Каршы якны билгеле бер сызыкка кадәр өстерәп китерергә яки берәр нәрсәне үзеңә (командаңа) алырга теләп, үзара тартышып уйнала торган уен. *Менә болар [кырмыскалар] булдыралар ичмасам. Кара, ничек тартыш уйныйлар.* Ж.Тәрҗеманов

4) Көрәш; ярыш. *Һәрбер тартыштан соң тамашачылар гөр килә, халык басып-басып карый иде.* Н.Әхмәдиев

5) *күч.* Өстенлек өчен көрәш; бәхәс; дәгъва. *Күрәсең, беренчелек өчен тартыш акыллы җүләрләр арасында гына бармыйдыр...* М.Галиев. *Егетнең мәхәббәте өчен көрәштә ике кыз үзара тартышка кермиләр, чөнки алар берберсен белмиләр.* А.Әхмәдуллин

6) *күч.* Үзара тыныша алмау, шаушу, җәнҗал. *Шулай бетте боларда сүз вә тартыш, Күрергә булдылар нәүбәт белән эш.* Г.Тукай. *Иллә эш бирнәгә барып җиткәч, ике арада бәхәс вә тартыш купкан.* М.Хәбибуллин

**ТАРТЫШКАК** *с.* Киреләнә, тартыша торган. *Арык кәҗә – тартышкак.* Мәкаль

**ТАРТЫШЛЫ** *с.* **1.** 1) Бәхәсле, тавышлы, җәнҗаллы, үзара көрәшле. *Съездның [солдатлар съездының] тартышлы, низаглы булачагы алдан ук мәгълүм.* М. Гафури

2) *сөйл.* Чама белән билгеле бер авырлыктагы. *Мин утырып торган бераз караңгырак фойега, үлчәүгә салсаң, кимендә йөз-йөз егерме килолар тартышлы, мәһабәт гәүдәле, сөйкемле, йөзен бераз чал кергән бөдрә сакал бизәгән бер ир уртасы чыкты.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ. к.* **тартыш** (*3 мәгъ.*). *Ике кичнең берендә я бала-чага арасында бил алышу үткәрәләр ирләр, я ятьмәләр белән күлнең астын өскә китереп бетерәләр, я, аркан тартышлы ярышы оештырып, бер-берсенә чирәм сөрдертәләр.* В.Имамов

**ТАРТЫ́Ш-ТАЛАШ** *җый. и.* Тартышу, талашу, ызгышу күренеше. *Торган саен ыгы-зыгы, тартыш-талаш арта барды.* М.Хәсәнов

**ТАРТЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тарту** II (*4–9 мәгъ.*). *Тауларда Барый абый арбамны тартышып менә.* Р.Газиз. *Ихтыяр аның тирәсендә әвәрә килеп йөри: агач ышкылый, пычкының бер башыннан тартыша.* Р.Вәлиев

2) Аркан, бау, таяк кебек нәрсәләрнең ике башыннан ике уенчы (команда) тотып, шул нәрсәне һәркайсы үз ягына тартып, каршы якны билгеләнгән сызыктан чыгарырга тырышу. *Йөгерешәләр, чүлмәк ваталар, аркан тартышып уйныйлар, хәтта ат чабышлары да булып ала.* Г.Бәширов

3) Көрәшү; көч сынашу. *Алар [батырлар] бер-берсе белән яртышар сәгать тартышалар.* М.Галиев

4) Берәр якка тарткан, этәргән көчкә каршы тору. *[Ишәк], хуҗаның тартуына карышканга, Кереште аяк терәп тартышырга.* М.Гафури. *Нечкәбил карыша, җил белән тартыша.* А.Алиш

5) Үзара тарткалашу. *Алар [малайлар] инде, җим өчен тартышкан чыпчыклар кебек, юл тузанында көрмәкләшәләр иде.* Г.Гобәй

6) Карышу, кычкырышу, бәхәсләшү. *Ул – минем көндезге танышым: биргән бүләкне алмыйча тартышкан әлеге Мәрвибану карчык булып чыкты.* Ф.Хөсни. *Вадим Денисовичны кунак итү өчен, Вера белән Солтанъяр икәүләп тартыштылар, әмма профессор үзе Назаровларга китте.* З.Мурсиев

7) Киеренке көрәш алып бару. *Ул туган елны, сыйнфый көрәш бугазгабугаз, үнәчкә-үнәч килеп тартышкан елны, кан елгалары яңгыр сулары белән бергә акты.* А.Алиш

8) Мускулларның рефлектив кыскаруы нәтиҗәсендә тәндәге кайбер урыннар җыерылу, тартылып кую; көзән җыеру. *Илһамның йодриклары гына түгел, иреннәре, күзләре дә ачу белән кысылды, уң як яңагы дерт-дерт тартышты.* Ф.Садриев. *Муенында сулык-сулык итеп яралар тартыша, нииндидер ачы төен, сулыш алган саен, күкрәген яндырып-көйдереп үтә иде.* В.Имамов

9) Калтырану, кинәт калтырап-калтырап кую. *[Мәдинә] тартышып-тартышып үксүендә дәвам итә иде.* Ш.Камал

**Тартыша башлау** Тартышырга тотыну. *Афзал абзыйны тыңлап утырганда ук, миндә ирексездән ике төрле уй үзара тартыша башлады.* Ә.Еники. *Пётр кисәк урыныннан сикереп торды, бөтен тәне бизгәк тоткандагы шикелле калтырана, тартыша башлады.* В.Имамов

**Тартыша тору** Даими, өзлексез тартышу; әледән-әле тартышу; әле тартышу. *Тартыша торгач, типография хуҗасы эш хакын бераз арттырырга күнде.* Ш.Камал. *Җил белән тартыша торгач Алга да, артка да, Пумала юк була. Әбидә сап кала.* Н.Исәнбәт

**Тартышып алу** Аз гына тартышу. *Ләкин Шимбай хан Көнбаш атакайга җавап бирер хәлдә түгел иде инде: аның башы кисәк бер якка авышты, гәүдәсе тартышып алды һәм сузылып тынып калды.* М.Хәбибуллин. *Картның җыерчыклы йөзе тартышып алды.* Г.Гыйльманов

**Тартышып бетү** Тәмам, бик нык тартышу. *Ябыгып, тартышып беткән сәрхуш гәүдәсенә элеп куйган костюм аның аптыраулы, оялып-кыенсынып кына карап торган чыраена бер дә килешми иде.* Ә.Дусайлы

**Тартышып калу** Берәр тәэсирдән соң тартышкан торышта булу. *[Качкынның] тартышып калды кинәт көчсез аягы һәм кулы.* Н.Исәнбәт

**Тартышып китү** Кинәт тартышу. *Ачуы чыкканда, аның гел шулай борын яфраклары тартышып китә иде.* Ә.Хәсәнов

**Тартышып кую** Бер тапкыр, кинәт тартышу. *Авыруның агарынып калган, буразналар сызылган ябык йөзе тартышып куйды.* С.Зыялы. *Ир көзән җыергандагы кебек тартышып куйды.* Ф.Җамалетдинова

**Тартышып тору** Әле тартышу; даими яки әледән-әле тартышу. – *Нәрсәгәдер йөрәгем чәнчеп, күз кабакларым тартышып тора әле, – диде ул һәм түр бүлмәгә кереп ятты.* Р.Вәлиев

**ТАРУ** I *и.* Кыр, тарлау. *Артыбыздагы чалуда Киндер җәяләр таруга.* Җыр

**ТАРУ** II *ф.* 1) Гадәттә, кирәкмәгән нәрсәгә юлыгу, тап булу; очрыйсы килмәгәнгә очрау. *Ясәви абзый, ничекләр итеп әлеге бәхетсезлекләргә тарыдың соң әле син?..* М.Хәсәнов. *Резин көймәдә берүзе Атлантик океанны кисеп чыккан француз галиме Ален Бомбар әйтә: «Диңгездә бәхетсезлеккә тарыган кеше каушамаска, башын югалтмаска тиеш», – ди...* А.Тимергалин

2) Гомумән очрау, тап булу. *Балшикәрдән артык сөяр идем, Кайчан кул гынама тарырсың.* Җыр. *Тарысаң тары ярыңа – Сөймәгәнгә тарыма.* Җыр

**Тарып алу** Бер тапкыр тару. *Ләкин шушы араларда бер маҗарага тарып алды.* З.Мурсиев

**Тарып бетү** Кат-кат тару. *Син әтрәкәләм аркасында әллә ниләргә тарып бетәм бугай инде.* Кәеф ничек?

**Тарып кую** Кинәт тару; бер кат тару. *Әйтим микән, улым, юк микән: ул филшыр кыз үзе дә бәлагә тарып куйды бит әле.* З.Мурсиев

**ТАРУ́ БУЛУ** *ф.* Көтмәгәндә очрау, тару, эләгү. *Аруга тару бул!* Әйтем

**ТАРХАН** *и. монг.* 1) *тар.* Алтын Урда һәм татар ханлыкларында ханга буйсынган, әмма ясак түләүдән азат ителгән вассал, өстен хокукларга ия феодал. *Син курыкма, каравылбаш Ташкари, фәрман дөрес, тархан мөһере дә*

*сиңа таныштыр.* М.Хәбибуллин. *Аннары биләргә, ыру башларына, тарханнарга исәнлек, бөтен Болгар йортка байлык, тынычлык теләде [ул].* Н.Фәттах

2) Ханның ышанычын яулаган кинәшче. *Олы атаң Елкыбайдай Туктамышка баш ими, Чын тарханым син булып, Корбым булсаң ни булгай?* Дастан

3) *тар.* Мәскәү патшалыгында һәм XIX гасырга кадәр рус империясендә кайбер татар морзаларына бирелгән рәсми титул; шундый титулы булган зат

4) XVIII–XIX гасырларда Россиянең үзәк өлкәләреннән үзләштерелмәгән җирләргә үз ирке белән килеп утырган һәм рәсми салым түләми торган крестьян. *Авылның тарханнар очы*

5) *фольк.* Күмәк уенны башлап җибәрүче, аны алып баручы, узаман. *Уенга [сан уенына] катнашучы бөтен кешегә тархан сан биреп чыга.* Җырлыбиюле уеннар

6) *күч.* Бәйсезлек, һичкемгә буйсынмаганлык. *Күрәсең, юкка гына, ат яхшысы арканда, ир яхшысы тарханда – иректә, дигән мәкаль барлыкка килмәгәндер.* Р.Кәрами

◊ **Тархан яту** *иск.* Ваемсыз, гамьсез вакыт уздыру

**ТАРХАНЛЫК** *и.* 1) Тархан (*1 мәгъ.*) хокукы; тархан (*1 мәгъ.*) дәрәҗәсе. *Бу тарханлыкны теләсә кемгә, байлык, хезмәтенә карап, хан гына «ярлыкфәрман» язып бирә алган.* Г.Гобәйдуллин. *Илһам хан заманнарындагы ярлыкларның төптәгеләре, ясак, салым вә тарханлыкка багышланган кәгазьләрнең юкка чыгуы --- турында сөйләшү өчен, Җан Гали хан махсус диван мәҗлесе җыйнатты.* Р.Батулла

2) Башында тархан торган һәм мирас буларак атадан балага күчкән җир биләмәсе. *Әле күптән түгел генә Һиндстанда Урта гасырлардан сакланып калган 562 ханлык, солтанатлар һәм тарханлыклар яшәп килгән.* М.Мәхмүтов

3) Тархан (*3 мәгъ.*) булу хокукы һәм дәрәҗәсе. *Питр патшаның үз кулыннан тарханлыкка ярлык алган инсан.* В.Имамов

4) *күч.* Бәйсезлек, ирек; иркенлек; иркен тормыш. *Башы исән калган терлекләргә бөтен җирдә тарханлык, алда үзләрен мул азыклы кыш көтә иде.* Ф.Хөсни

**ТАРХАНЧЫЛЫК** *и. тар.* Тархан ярлыклары бирү-бирелү системасы. *Шулай ук тарханчылык та барлыкка килә.* Ф.Вәлиев

**ТАРЧЫЛЫК** *и. сөйл. к.* **тарлык** (*3 мәгъ.*). *Тарчылык булмый киңчелек булмый.* Мәкаль

**ТАРЫ** I *и.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан орлыклары себеркәчтә җитешә торган берьеллык үсемлек, бөртекле авыл хуҗалыгы культурасы; *русчасы*: **просо**. *Тәнзилә ял вакытлары исәбенә тары утарга йөри, киндер йолкырга...* А.Гыйләҗев. *Уналты мең гектарда чәчелгән бодай, тары, көнбагыш өлгереп килә.* А.Хәсәнов

2) Шул үсемлекнең вак сары орлыгы – бөртекле ашлык. *Тавык төшенә тары кергән, чүпләп бетермәгән – тагы кергән.* Мәкаль. *Ындыр табагыннан борчак, тары чәлдерүләр турында да озын колактан ишетелгәли.* А.Гыйләҗев

3) Шул ашлыкның ашарга яраклы ярмасы яки оны. *Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул [Мәүлихә], чирәм өстендәге куна тактасыннан бер тәлинкә алып, аны үзенә хас пөхтәлек һәм иплелек белән һәйбәтләп сөртте дә аңа мул гына итеп тары боткасы салды.* Г.Бәширов. *Ничә елдан бирле Равилнең төшенә дә кермәгән ит бәлеше, ап-ак оннан йомыркага изеп кенә пешерелгән кош теле, тары кыстыбые һәм юкә балы белән сыйлаганнан соң, Рухия Равилне клубка бәйрәм кичәсенә алып китә.* В.Нуруллин

**ТАРЫ** II *и. иск.* 1) Урта Азиядә эшләнеп, шуннан китерелә торган скрипка төре

2) Думбрадай чиртеп уйнала торган, башлыча Кавказ ягында таралган озын саплы кыллы музыка коралы. *Пир Исрафил, тарыны кулына алып, күңелнең бөтен серләрен ачып бирә торган бер көй уйный башлап, кычкырып җырлап җибәрде.* Г.Газиз

**ТА́РЫ-БАРЫ** *җый. и. рус сөйл.* Вак-төяк, ыбыр-чыбыр нәрсәләр. *Әй, пешмәгән, ачык авыз! Юкны эзләп йөргәнче, тары-бары гына аласың калган.* Ш.Камал

**ТАРЫГУ** I *ф.* 1) Билгеле бер яшәү шартларыннан ялыгу, нәрсәдәндер туяу, кыенсыну. *Шыксыз өчәр яруслы казармадан ул, җаны тарыгып, шәһәргә ыргыла.* М.Галиев. *Бар иде бер Габдулла. Шигырь язды – ялыкмады, Язудан һич тарыкмады --- .* И.Хәйруллин

2) *сир.* Җәберсенү, үчегү. *Изгелеккә юллар ябык түгел, Тарыкмасын бары күңелләр.* Ф.Шәрипова

3) Нәрсәне дә булса күпсенү, күрәлмәү. *Аларның [шигырьләрнең] чыгуына тарыгалар дип уйланмасын: матбугат базары киң.* Г.Ибраһимов

**Тарыга башлау** Тарыгырга тотыну

**Тарыга төшү** Бераз тарыгу

**Тарыгып бетү** Бик нык тарыгу

**Тарыгып тору** Даими яки әледәнәле тарыгу; өзлексез тарыгу, әле тарыгу

**Тарыгып яту** *сөйл. к.* **тарыгып тору**. *Күкрәккә тулышкан саф һава канны уйнатып, тәнне җиңеләйтә. Нәфисә тарыгып яткан тән көченең, канатланып, каядыр омтылуын тоя ---.* Г.Бәширов

**ТАРЫГУ** II *ф.* Тару, очрау. *[С.Рәмиев] аз сүзле, түземле, ниндидер чишелмәс проблемалар һәм уй-кичерешләр сарып алган, рухи газапларга тарыккан моңсу кеше.* С.Кудаш

**ТАРЫГЫ́П-ЗАРЫГЫП** *рәв.* Бик нык юксынып, зар-интизар булып. *Шулай итеп, без тарыгып-зарыгып көттек.* Ак юл

**ТАРЫЗ** *и. гар иск.* **1.** *кит.* Төс, рәвеш; ысул. *Өстән генә әлəктереп китү тарызын алган сәяхәтнамә өчен, Уфада артык нәрсә күрмәдем бугай.* Г.Тукай. *Безнең милләтемезгә дә Гоголь тарызында яза торган мөхәррирләр бик кирәк иде.* Г.Исхакый

**2.** *бәйл. функ. иск.* Төсле, рәвештә. *Шул тарыз кайтып җитү*

**ТАРЫЗЛЫ** *рәв. иск.* Төсле, рәвешле

**ТАРЫЙ** *и. иск. к.* **тары** II. *Эскерипкәм тарый, тарый, Тарый булса да ярый.* Җыр

**ТАРЫКТЫРУ** *ф. кит.* 1) *йөкл. юн. к.* **тарыгу**. *Эшсезлек тарыктыра*

2) *зат-сыз* Тарыгырга туры килү. *Тәмам тарыктырды инде*

**ТАС** *и.* Түгәрәк яки овал формалы, ешрак кер юу өчен кулланыла торган

киң һәм сай савыт; таз. *Үзәк чан янында махсус таска яшькелтрәк төстәге ярым сыек болгар сабыны салынган иде.* А.Тимергалин

**ТА́С БУЛУ** *ф. диал.* Ару-талу, йончу, йөдәү. *Иртәгесен әти уяткач, күзне ача алмый тас булдым: әле генә яткан идек түгелме соң?* Ш.Маннур

**ТАСВИР** *и. гар.* 1) Билгеле бер вакыйга, күренеш һ.б.ш.ның сүзләр белән сурәтләнеп бирелеше. *Безнең уртак бәйрәмгәме ул – бүлмәң Бизәлгән?Аһ, тасвирына сүз белмәм.* Р.Гаташ

2) Берәр күренеш, хәл, вакыйганы гомумиләштереп күрсәтә торган тәфсилле сурәтләмә. *Галиәсгар әфәндедәнең бу ике әсәре – чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар.* Г.Тукай

**ТАСВИРӘТ** *и. иск. гар.* Тасвирлау, тасвирлану күренеше. *[Зарифаның] тасвирәте актык нокталарына җиткәч, һәр сөйләүдә тавышы үзгәрә, күзе яшәрә дә яулыгы белән сөртә башлый.* Г.Ибраһимов

**ТАСВИРӘТЛЕ** *с. иск.* 1) Матур. *Тасвирәтле күренеш*

2) Сәнгатьле, образлы. *Тасвирәтле сөйләм*

**ТАСВИРИ** *с. гар.* Тасвирланган, тасвирлы итеп сурәтләнгән; тасвирлауга хезмәт итә торган. *Мавыктыргыч сюжет төзүгә һәм моның өчен вакыйгалылыкка йөз тотып, З.Бигиев хикәяләүнең тасвири ягына азрак дикъкать итә.* М.Гайнетдинов. *Алар арасындагы мәхәббәт Фәрһад вә Ширин, Таһир илә Зөһрә һ.б. тасвири гыйшык ияләренең бетмәс-төкәнмәс кайнар утларыннан да көчлерәк вә шагыйранә бөегрәк иде.* Ф.Яхин

**ТАСВИРИ́ СӘНГАТЬ** *и.* Рәсем сәнгате, графика һәм сынлы сәнгатьне берләштергән, чынбарлыкны күренә, күз белән кабул ителә торган итеп чагылдырган пластик сәнгать төре. *Тасвири сәнгатьнең үзенә бер төре саналган Казан плакаты турында күп кенә әдәби хезмәтләр бар.* Фәнни Татарстан

**ТАСВИ́Р ИТҮ** *ф. к.* **тасвирлау**. *– Мин тасвир иткән хатын белән син карчык өендә күргән хатын арасында охшашлык юкмы? – дип сорады.* З.Бигиев. *Үткәннәрдә калган әкияти авыл табынын тасвир итеп тормыйбыз.* А.Тимергалин

**ТАСВИ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тасвирлау**. *Син күрмәгәч, ничек тасвир кылыйк имди?!* Кол Гали. *Барлык геройларның да туганнан бирле гашыйк булган, йөргән һәммә кызларын тасвир кылу кирәкмәс иде.* Ш.Алпар

**ТАСВИРЛАМА** *и.* **1.** 1) Тасвир, тасвирлау өчен кулланылган чара. *Китапта кыямәт, оҗмах, тәмуг укучының күңелен әсәрләндерерлек тасвирламалар белән сурәтләнә.* Д.Абдуллина

2) Берәр китап, кульъязма һ.б.ш.ның палеографиясен һәм эчтәлеген кыскача аңлатып биргән мәкалә. *Габдрахман Таһирҗанов, дәвамлы һәм эзлекле рәвештә, Ленинград дәүләт университетының шәрык факультетындагы фарсы, төрки, гарәп телләрендәге кульъязмаларны өйрәнә, тасвирламалар чыгара ---.* Т.Әйди

3) *лингв.* Телне синхрон планда өйрәнә торган. *Тасвирлама лингвистика*

4) *лингв.* Сүзнең мәгънәсен чынбарлыктагы объектны тасвирлап аңлатып бирү юлы белән ачкан. *Тасвирлама дефиниция*

**2.** *с. мәгъ.* Тасвир рәвешендәге, тасвир хезмәтен үтәгән. *Ләкин әлеге хезмәтләрдә татар халкының рухи дөньясы, көндәлек тормышы, көнкүреше этнография фәне материалы буларак яктыртыла, һәм әлеге материал бары тик тасвирлама характерда бирелә.* З.Арикеева

**ТАСВИРЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса сүзләр ярдәмендә сурәтләп бирү, тасвирлар белән сөйләү яки язу. *Мин – күктәге, Лотфи җирдәге фашистлар белән бәрелешләр турында аеруча хәтергә сеңеп калган эпизодларны тетрәндерерлек итеп тасвирладык.* Ф.Хуҗин. *Хатынның бу минутларда кичергән хисләрен тасвирларга сүзләр җитмәс иде.* Ф.Абдуллин

2) Нәрсәне яки кемне дә булса рәсемдә, картинада сурәтләү. *Гүя рәсемдә аның: «Туган ягымның батыр улын харап итәләр, үтерәләр!» – диеп кычкырган мәле тасвирланган.* А.Мансуров

**Тасвирлап алу** Тиз генә тасвирлау

**Тасвирлап бару** Даими, билгеле бер вакыт дәвамында тасвирлау. *Дөрес, халык арасында әнә шулай вакыйгаларны теркәп, аларга бәя биреп, тасвирлап баручылар булуы бик яхшы инде ул.* З.Мурсиев

**Тасвирлап бетерү** Тулысынча тасвирлау, һәрьяклап тасвирлау. *Әйтеп тә, тасвирлап та бетереп булмый торган илаһи, сихри мизгел иде бу!* Г.Гыйльманов. *Соңгы курста, табигатьнең иң матур, рәссамнар да тасвирлап бетерә алмаган мәлендә, керсез җаннар кебек пакь, алсу ак алмагач чәчәкләренә күмелеп утырган чагында, алар өйләнештеләр.* Г.Исхакова

**Тасвирлап бирү** Тулысынча, бөтен ягын ачып тасвирлау. *Алтын куллы Габдрахман абзыйның мөлаем образын автор ялкынлы пафос белән, --- реалистик буяулар белән, оптимистик рухта, сокланып үләрлек итеп тасвирлап биргән.* Г.Афзал. *Аның пешергән ипи, кабартмаларының тәмен язучы шундый оста тасвирлап бирә: безнең дә авыздан сулар килә.* Г.Гобәй

**Тасвирлап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, кирәк кадәренчә тасвирлау. *Каләмем бу кадәр моң-сагышны сурәтләп, тасвирлап та җиткерә алмады кебек.* Ф.Яхин

**Тасвирлап китү** Сүз уңаеннан, эш барышында гына тасвирлау. *Автор болар арасында В.Кар, Ф.Венцель, Я.Данненберг, А.Корф --- һәм башка дистәләгән алман хәрби җитәкчеләрен атый һәм аларның киңкырлы «эшчәнлеген» тасвирлап китә.* В.Имамов. *Тәбрис Галиев белән булган бер кызык вакыйганы да тасвирлап китик инде.* Т.Нәҗмиев

**Тасвирлап тору** Әле, хәзер тасвирлау; даими яки әледән-әле тасвирлау. *Яңадан тасвирлап торуның кирәге юк.* З.Мурсиев

**Тасвирлап узу** *к.* **тасвирлап үтү**. *Чөнки югарыда инде тасвирлап уздык: Пугачёвның Кама аша кичүен белгәннән соң, Венцель, Клепиков, Алымовлар әлеге ике заводтан нибары 1500 эшчене генә, туплап, «падишаһ»ка «каршы» юллый алганнар.* В.Имамов

**Тасвирлап үтү** Эш яки сүз уңаеннан тасвирлау. *Хәзер Бөре тирәсендәге*

*фетнә хәрәкәтен тасвирлап үтик.* В.Имамов. *Шул ният белән берничәсен санап, алай гына да түгел, шуларга кагылышлы вакыйгаларны кыскача гына сөйләп һәм тасвирлап та үтәргә ниятлим.* Ф.Баттал

**Тасвирлап чыгу** Һәммәсен тасвирлау. *Туфан абыйның яшәеш нечкәлекләренә, язучыларча әйтсәк, детальләргә артык тирән кермичә генә тасвирлап чыктым да уйга калдым ---.* Т.Нәҗмиев

**Тасвирлый бару** Һәммәсен эзлекле рәвештә тасвирлау

**Тасвирлый башлау** Тасвирларга тотыну. *Аннан [ул], эчмәсәң, эчмә дигәндәй, бер-бер артлы стаканын тутырып салып эчте дә тагы да әтигә карата үзенең якын хисләрен тасвирлый башлады ---.* Л.Таналин. *Бөек гаскәр башлыклары Атилла, Искәндәр, Батый, Аксак Тимер, Чыңгыз хан, Суворов кебек даһиларның тарихи җиңүләрен тасвирлый башлый [ул].* З.Мурсиев

**Тасвирлый тору** *к.* **тасвирлый бару**. *Лилия һәркайсын оста итеп тасвирлый тора, чатта туктаткан ГИБДД хезмәткәре дә, кибеттә дорфа кыланган сатучы да, хастаханәдәге үшән табибә дә, булдыксыз чиновник та бөтен холык-фигыльләре белән күз алдыннан үтә тора.* Сөембикә

**ТАСВИРЛЫ** *с.* Махсус алымнар, чаралар ярдәмендә тасвирланган; тасвир чараларына бай булган. *Ә әдәби иҗатка керешүчеләргә тасвирлы «нечкәлекләр»нең серләренә тирәнтен төшенүдә инә белән коены иренмичә үзләре казу мәҗбүри.* М.Хуҗин. *Тирән тәэсирле Фатыйма исемле кызчыкның күңелендә беренче тапкыр шигъри хыяллар җилпенүе, тасвирлы сүзнең ләззәтен сиземли башлавы нәкъ әнә шул абыстайга йөри башлаган вакытларга туры килгән дә инде.* М.Рафиков

**ТАСВИРЛЫЛЫК** *и.* Тасвирлы булу; образлылык; җентеклелек. *Шул ук вакытта аның лирик пейзажларында Татарстанның милли үзенчәлеген чагылдыручы билгеләр: кабатланмас мотивлар, бу җирнең үз буяулары, тасвирлылыкны, декоратив гүзәллекне һәм матурлыкны халыкчан күзаллау – барысы да бар.* Казан утлары

**ТАСВИРЧЫ** *и.* Тасвир итүче, оста тасвирлаучы кеше. *Тарихчы вакыйгалар тасвирчысы гына түгел.* Әйтем. *Хатирә формасында язылган «Ыссык Күл» (1913) исемле очеркы Г.Рәфикый иҗатының яңа ягын ача: монда ул оста пейзажчы, тасвирчы, табигатьне нечкәләп күзәтүче ---.* Ф.Ибраһимова

**ТАСВИРЧЫЛЫК** *и.* Тасвир итү, тасвирлау белән мавыгу күренеше. *Гомумән, шагыйрәне Дәрдемәндкә акыл, рух, сүз камиллегенә омтылу, тасвирчылыктан арыну, яшәешебездән эчке мәгънә эзләү, үз-үзеннән канәгатьсезлек һәм шигырьне гел төрләндереп тору рухы якынлаштыра ---.* Т.Галиуллин

**ТАСКАК** *и. диал.* 1) Агач башында җәнлек күзәтү өчен яки ачык һавада кайбер ашамлыкларны киптереп әзерләү өчен киштә. *Корыт – ачык таскакта киптерелә торган эремчек йомгаклары.* Безнең мирас

2) *сөйл.* Идән такталарының берсе, сайгак

3) Баганаларга күтәртеп җәелгән тезмә; төзелеш басмасы. *Алюминийдан эшләнгән 38–50 мм диаметрлы торбалар җыелма-сүтелмә таскак (леса) һәм басмалар җыйганда кулланыла.* Төзү материаллары

4) Урман кисү, агач эшкәртү һ.б.ш. эшләрдә агачны кирәк якка аудару яки күтәртеп тору өчен кыстырылган чөй яки агач кисәге; авыш түшәмә. *Кызгылт кабыклары чыелган юан нарат- лар, авыш таскаклар ягына чыгу белән, дөпелдәп түбән тәгәри.* Н.Фәттах. *Пычкы кысылмасынга таскак ясыйбыз.* Безнең мирас

**ТАСКАРА** *и.* Карчыга кошлар семьялыгыннан ак башлы ерткыч кош; *русчасы:* **сип белоголовый**

**ТАСЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **таслау**. *Үз сандыгымда күпме бирнә чүпрәкләрем тасланган килеш ята...* А.Хәлим. *Шунда ук имән агачыннан юнылган, тасланган авыр хач та тора.* А.Гыйләҗев

**Таслана төшү** Бераз таслану

**Тасланып бетү** Тәмам, бик нык таслану. *Ниһаять, кунычта ятып тасланып беткән өчлек Шәрифелттинең калтыранган кулларыннан фалчының уч төбенә күчте.* Н.Кәримова

**ТАСЛАП** *рәв.* Тәртип белән; җай белән. *Менә шулайрак итеп таслап сөйли Евгений үз башыннан кичкәннәрне.* Ватаным Татарстан

**ТАСЛА́У** *ф.* 1) Тигезләп, тәртип белән төреп, бөкләп кую. *Барысын да сандыгыннан чыгарып сыйпап утырыр иде дә яңадан таслап алып куяр иде [ул].* Р.Сәгъди. *Мәҗлес азагында илчеләргә ике кенәз дә кыйммәтле кеш туны, хатыннары өчен күлмәклек – тасланган кытай ефәге, ике олы илчегә – Атабай белән Тукыл бәккә – асылташлы хәнҗәр бүләк иттеләр.* Р.Батулла

2) Юнып тигезләү, юнып шомарту. *Бүрәнәләрен инде китергәннәр, рәшәткә янына таслап өйгәннәр, форсат чыкканчы гына көтәләр, эһ дигәнче бурап күтәреп мүкләп куячаклар.* Т.Миңнуллин. *Каргалар өере башында дәү козгын – керфексез ала күзле, утын түмәрләрен таслап бергә укмаштырган гәүдәле, сип-симез, икенче катта яшәүче полковник хатыны Өммегөлсем иде.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Тәртипкә салу, матурайту. *Киләдер дөньяны таслыйсы, телемнең – җылы сүз әйтәсе, йөрәкнең – яшьлеккә кайтасы...* Р.Харис

4) *күч.* Кемне дә булса берәр гаебе өчен каты шелтәләү, тиргәү; кирәген бирү, акылга утырту. *Белмим, мужикны тасларгамы, әллә офицерларны юныштырыргамы?* А.Гыйләҗев

**Таслап алу** Бераз таслау; аз гына таслау

**Таслап бару** Эзлекле рәвештә таслау. *Компьютер – кешенең хаотик рәвештә я булмаса нәүбәтен көтмичә алданрак туган фикерләрен кирәге чыгар әле дип туплап, таслап баручы хәтер капчыгы да.* Р.Харис

**Таслап бетерү** Бик нык таслау

**Таслап тору** Әле, хәзер таслау; даими яисә әледән-әле таслау. *Олы ташлар кузгаталар, Чүкечлиләр, шомарталар; Кайсы измә ясап тора, Кайсы такта таслап тора.* Ш.Маннур

**Таслап чыгу** Барысын да таслау

**Таслый бару** Һәммәсен эзлекле рәвештә таслау

**Таслый башлау** Тасларга тотыну. *Осталар, килеп, бүрәнәне таслый башлагач, янә бер кыл чыртлап өзелгәнен ул үзе сизде.* Р.Мулланурова

**Таслый төшү** Бераз таслау

**ТАСМА** *и.* **1**. 1) Бизәү, бизәнү, кием-салымны һ.б.ш. матурлау, уратып бәйләү өчен, шулай ук кием-салымга беркетелгән шартлы билге сыйфатында да кулланыла торган тар һәм озын тукыма. *Аның ике ягында беләкләренә шулай ук тасмалар бәйләгән ике кеше атлый.* Г.Әпсәләмов. *Без исә бу Сабан туена ямь-яшел тарантаска өсте ялык-йолык килеп торган, ал, кызыл тасмалар кушып үргән тузгак яллары кочагыңа сыймас капкара айгыр Чегәнне җигеп төшкән идек.* А.Хәсәнов

2) Һәртөрле тар һәм озын тукыма, кайры, юкә яки шулар ишенең телемнәре һ.б. *Мин аның гәүдәсенә сыланып кына торган киеменә, ике канат сурәте төшерелгән алтын кокардалы фуражкасына, көзге кебек ялтырап торган кара лаклы ботинкаларына, иңендәге алтын тасмалы погоннарына исләрем китеп карап тордым.* В.Нуруллин. *Карт, ишек төбе тулып яткан юкә тасмаларны тезенә җәеп, бау ишеп утыра иде.* Г.Гыйльманов

3) Гомумән юка тар һәм озын әйбер. *Азат сөйләгәннәрне магнитофон тасмасына язып калмавыма хәзер үкенеп бетә алмыйм.* А.Тимергалин. *Табиблар бүлмәсендә Маһирә ханым Гөлшәһидәләргә электрокардиограмма тасмасын, кан анализларын күрсәтте.* Г.Әпсәләмов

4) Патроннар өчен каеш яки металл лентага беркетелгән оялар теземе. *Пулемётчы үзе манма су булса булсын, патрон тасмасы юешләнмәсен!* З.Зәйнуллин. *Шушы алыш вакытында ул алты пулемёт тасмасын бушатып өлгергән икән.* З.Мурсиев

**2**. *с. мәгъ.* 1) Тасма (*1 мәгъ.*) рәвешендәге; тасмадан гыйбарәт булган. *Агай тасма дилбегәне кулына алды да, кәләпүшен төзәтеп, атына сүз катты. Кузгалып киттеләр.* И.Гази

2) Тасма (*1 мәгъ.*) кебек тигез, такыр. *Бары тик Рим каласына таба сузылган таш җәйгән тасма юлга төшкәч кенә атын тыйды.* М.Хәбибуллин

3) *күч.* Ягымлы итеп, кемгәдер яраргa тырышып сөйли белгән. *Тик син, чибәр егет, тасма телләреңне бушка әрәм итмә, киләчәккә сакла!* Г.Бәширов. *Ул шулай тузга язмаганнарны лыгырдап утырган вакытта, мин, Хәмидә апа бу ахмакның тасма теленә ышанып куймаса гына ярар иде дип куркып, гел аңа гына карап утырдым.* В.Нуруллин

**ТАСМАЛ** *и. фар. этн.* Яшь кызлар һәм хатыннар бәйли торган чигүле озынча яулык. *Баш яулыкларының төрләре һәм атамалары байтак --- шәльяулык, тасмал, өрпәк, мәндил һ.б.* А.Тимергалин

**ТАСМАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тасмалау**

2) *кайт. юн. к.* **тасмалау**. *Кара чәчләре, тасмаланып, нәфис муенына, күкрәкләренә чорналган.* Ш.Шәйдуллин

3) Тасма формасына керү; тасма сыман булу. *Узган елгы чирәме инде саргайган, быелгысы әле баш калкытып өлгермәгән, шулай да ике басу арасындагы бу межа кара җирдә әллә кайдан ук тасмаланып яшәреп ята.* Ф.Хөсни

**Тасмалана бару** Акрынлап тасмалану

**Тасмалана төшү** Бераз тасмалану

**Тасмаланып бетү** Тәмам тасмалану

**Тасмаланып кую** Кинәт тасмалану

**Тасмаланып тору** Тасма булып күренү

**ТАСМАЛА́У** *ф.* 1) Тасма белән бизәү, матурлау. *Өсләрендә озын итәкле, озын җиңле куе яшел төстәге күлмәкләр, үзләре яланбаш, чәчләрен матур итеп тасмалап үргәннәр.* Ф.Мөслимова

2) Тасмаларга телгәләү, тасма-тасма итеп кисү, тураклау. *Озынчалап бүленгән кыярны тасмалап кисәләр.* Ватаным Татарстан

3) Тасма рәвешенә китерү. *Хуш исле болын гөлләрен Чалгым тасмалап сала.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

4) *күч.* Буй-буй сызыклар белән каплау. *Киң, шома, нык, матур юллар корыган, кипкән сазлык өсләрен тасмаладылар.* И.Туктар

**Тасмалап тору** Әле, хәзер тасмалау

**Тасмалый башлау** Тасмаларга тотыну

**Тасмалый тору** Әлегә тасмалау

**ТАСМАЛЫ** *с.* 1) Тасмасы булган; тасма белән үрелгән, тасма бәйләнгән. *Өстенә бушлат ябылган, йөзенә ефәк тасмалы бескозырка капланган Харьков егетенә алар озак карап тордылар.* Г.Әпсәләмов

2) Тасма рәвешендәге; тасма ярдәмендә эшли торган. *Хәзер аның трюмнарына тасмалы транспортёрлар ярдәмендә бодай төйиләр ---.* С.Сабиров

3) Тасмага төшерелгән (фильм тур.). --- *Нәриман урамындагы прокат базасыннан тар тасмалы фильмнар алып кайтып, укучы иптәшләренә кино күрсәтә, һәм шулай аның киномеханик даны тарала.* Т.Әйди

**ТАСМА́СУАЛЧАН** *и. зоол.* Кеше һәм хайваннарда паразитлык итүче озын тасма кебек гәүдәле яссы суалчан төре. *Тасма суалчаннарның күбесе умырткалы хайваннар организмында паразитлык итә.* Биология

**ТАСМА́-ТАСМА** *с.* **1.** Бик күп тасмалар рәвешендәге; телгәләнгән. *Елганың ике ярында да тасма-тасма ашлык басулары, яшелчә бакчалары*

**2.** *рәв. мәгъ.* Тасмалар рәвешендә; телгәләп. Тузгыган озын чәчләре тасма-тасма булып маңгаена төште, музыкантның ут булып янган күзләрен каплады. М.Хәсәнов. *Болай да теткәләнеп беткән бишмәтемне тасма-тасмага калдырып таласа?* А.Хәлим

**ТАСМАТЕЛ** *и.* 1) Ялагай, йомшак, ләкин буш сүз, оста тел белән үз фикерен кабул иттерә белгән кеше. *Мактаулардан түбәсе күккә тимәсме? Ләкин Алсу тасмателләргә ышана торган кыз булып чыкмады.* Ф.Яруллин

2) Телгә оста кеше

**ТАСМАТЕЛЛӘҮ** *ф.* Бик ягымлы итеп, кемгәдер яраргa тырышып сөйләү. *Егетләрнең бер өлеше кызлар янына килеп утыра, тасмателләнеп, аларны үбәргә, кочакларга маташкан булып кылана.* З.Мәхмүди. *– Бән сиңа сөйдерү бөтиләре өшкереп бирермен, кәбәм, аларны куллану серләренә дә өйрәтермен, – диде карчык, тасмателләнеп, – иреңә дога көче иңдерелгән сулар*

*эчерерсең, күзеңә генә карап торыр...* М.Әмирханов

**ТАСМА́ТЕЛЛЕ** *с.* Бик ягымлы сөйләшүче; оста телле. *Берәр тасмателле егет очрап, башымны әйләндереп куйса...* В.Нуруллин. *Шуңа карамастан, разведчиклар аны яратып өлгерделәр, әмма Березин, тасмателле булганы өчен, аны хөрмәт итми иде.* Г.Әпсәләмов

**ТАСМА́ЧЛАР** *и. күпл. зоол.* Нимфалидалар семьялыгыннан канатлары бер үзәктән чыккан тасмалар җыелмасын хәтерләткән ачык төсләрдәге күбәләкләр ыругы; *русчасы:* **ленточники**

**ТАСРА́ЙТУ** *ф.* 1) Куркудан, гаҗәпләнүдән, нидер көтеп күзләрне зур итеп ачу, тутырып карау. *Ә иң алда күзләрен тасрайтып, тешләрен ыржайтып карап торучысы – Күчәрбай башкисәре Мәхмүт Илмурзин...* В.Имамов. *Шакир, күзен тасрайтып, озак кына миңа карап торды ---.* Н.Гыйматдинова

2) Колак яфракларын торгызу. *Азмы-күпме йоклагач, егет «өнемме бу, төшемме бу» дип уянып китсә, барча хайваннар сикереп торып колакларын тасрайтканнар, ди.* Әкият

**Тасрайтып тору** Әле, хәзер тасрайту; тасрайган хәлдә булу. *Гафинең күзләре, бүренеке шикелле, ниндидер ачу белән уттай янып, астан тасраеп торалар иде.* Ш.Маннур. *Әнә шуннан Иблис үзе күзләрен тасрайтып торадыр шикелле.* З.Фәтхетдинов

**ТАСРАЮ** *ф.* 1) Куркудан, гаҗәпләнүдән, нидер көтеп, күзне зур ачып, текәлеп карау. *Ишектән тасрайган, арттан яулыгыны бәйләгән, алъяпкыч япкан асрау кыз килеп керә.* Г.Исхакый. *Бер-берсенә кушылып үскән куе кашлар астыннан текәлгән соргылт күзләрендә Андрейга тугрылык хисләре чагыла, тик тасрайган карашы кургаш сыман авыр.* В.Имамов

2) Сагаеп карау яки тыңлау

**Тасраеп калу** Ниндидер тәэсирдән соң кинәт тасраю. *[Ала мүкләк] өстенә ташланырга хәзерләнгән аю яки бүре күрдемени! Кинәт тасраеп калды.* М.Хәсәнов

**ТАСТАР** *и. фар. этн.* 1) Махсус агартылган нечкә җитен җепләрдән тукылган затлы ак киндер. *Хәстәрле кыз тастарлы.* Мәкаль

2) Кулдан тукылган озын сөлге

3) Яшь киленнәр баш-башларын салындырып урый торган һәм ак киндердән киселгән озынча яулык. *Кам Ана мөгезле тастарын, ябынча күк тәкә тиресен салып куйды, йокы булмәсенә кереп ятакка ауды.* Л.Зөлкарнәй

4) Бәбиләргә азык салып каптыра торган чүпрәкчә, имезлек. *Тастары баллы булгандыр – теле татлы.* Әйтем

**ТАСТЫМАЛ** *и. фар.* 1) Бил буу, кайбер нәрсәләрне уратып бәйләү, төрү, бүлмә бизәү һ.б.ш. өчен куллангыла торган, чигелгән яки бизәкләп тукылган озын сөлге. *Аларның якынлыкларына карап, әни күбесенчә кызыл башлы тастымалдан әтмәлләгән кеч-кенә капчыкларына я йомырка, я кызыл билле прәннек, я ак төш салып чыгара.* Г.Бәширов. *Өй челтәрле кашагалар, каюлы тастымаллар белән бизәлгән.* И.Хуҗин

2) Ашаганда, аш әзерләгәндә, нәрсәнедер сөртеп алу, корыту өчен кечерәк тукыма; салфетка, сөрткеч. *Итәккә тастымал салу*

**ТАСТЫМАЛЛЫК** *и.* **1.** Тастымал ясау өчен билгеләнгән тукыма. *Тастымаллыктан тегелгән ак күлмәк тә, тезгә генә җитеп торган гарадскуй кызыл ыштан да тәтеми аңарга.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Тастымалга китә торган. *Тастымаллык киндер*

**ТАСЫЛ** *и. диал.* 1) Эшнең җае, сере, аны башкару юлы, ысулы. *Тасылын белгән – таш кискән.* Мәкаль

2) Осталык, сәләт, талант. *Һәр эшкә тасыл кирәк.* Әйтем

**ТАСЫЛЛЫ** *с.* Берәр эшкә тасылы, осталыгы булган. *Тасыллы ипле куллarda кораллар уйнады, башы ЭВМдай шәп, тиз эшләде.* Д.Булатова

**ТАСЫРДА́У** *ф.* 1) Бик каты шатырдаган, чатыр-чытыр килгән тавыш чыгару; шатыр-шотыр килү. *Шулчак нидер баш очында гына Гөлт кабынды – очкын очырды. Афәт сизгән боландай, тасырдап, Сикереп үттем тирән чокырны...* А.Хәлим. *Аның мембраны бармакка гына тисен – мина, мең тегермән ташы тасырдаган тавышлар чыгарып, шартларга да күп сорамый.* С.Поварисов

2) Тынычсызлану, ярсу. *Кыз, йөрәге тасырдап тибә башлавын сизеп, чәен капты.* М.Яһудин. *Инде төш җитеп, җаны тасырдап өенә керүгә, беренче эше итеп, стенка янына түбәтәен барларга килде.* Р.Фәизов

3) Көч ташып тору. *Ул чакта без тасырдап, янып торган яшьләр идек шул.* Ә.Хәсәнов

**Тасырдап алу** Берникадәр вакыт кына тасырдау

**Тасырдап кую** Кинәт тасырдау; бер тапкыр тасырдау. *Җаным үкчәмә төшеп китте, йөрәк тасырдап куйды.* Т.Нәҗмиев

**Тасырдап тору** Әле, хәзер тасырдау; даими яки әледән-әле тасырдау. *Йөрәк түзми шул. Тасырдап тора.* Г.Камал. *Көне буе тасырдап торган канлы фронт яланы кинәт тынып калды.* С.Поварисов

**Тасырдый башлау** Тасырдарга тотыну. *Әмма аны күрсә, картның йөрәге тасырдый башлый, куллары калтырана.* З.Хөснияр. *--- икенче көнне үк аның йөрәге Сабантуйдан кайткан аттай тасырдый башлады.* Ә.Хәсәнов

**ТАСЫРДЫК** *с.* Тынычсыз, түземсез, тасырдап торган. *Ярату, гашыйк булу адәм баласының йөрәген яшүсмер чакта гына җилкетеп, еллар өстенә еллар өстәлүдән хасил булган Вакыт, торган саен, читлектәге кош баласыдай бәргәләнгән, тасырдык йөрәкне тынычландырып, урынына утыртып куяр төсле иде ләбаса!..* З.Хөснияр

**ТАСЫ́Р-ТАСЫР** *иярт.* Тигезлетигезсез йомшак юлдан йөгерү, чабу тавышын белдерә. *Нәкъ шул чакта иярле атка атланган бер егет, тасыр-тасыр чабып, капкадан чыгып китте: кияүгә никах укылуын хәбәр итәргә.* Ә.Еники

**ТАСЫ́Р-ТОСЫР** *иярт. к.* **тасыр-тасыр**. *Биш айгыр, артыннан куа чыгуны сизенгән кебек, киң дала буйлап Яман Чүл җәйләве ягына таба, ак юл булсын! дип, тасыр-тосыр чаптылар.* Г.Ибраһимов

**ТАТ** I *и.* Тәм, татым. *Акның аты [даны] бар, караның таты бар.* Мәкаль. *Бала чагы узган Сарман яклары-*

*ның тауларын да, киң кырлардан гына гыйбарәт тарафларын да, исендә өскә ишелеп торгандай куркыныч табигатьле булып сакланган кара урманнарны да, боз кебек салкын чишмә суларының татын да – барысын-барысын да хатирәләрендә яңарта.* Ф.Яхин

**ТАТ** II *и. фар.* Дагстанда һәм Азәрбайҗанда яшәүче иран телле халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Тат телендә сөйләшү*

**ТА-ТА** *иярт.* Пулемёт, автомат һ.б.ш. кораллардан атканда чыккан тавышны белдерә. *Вот пулемёт – корал ичмаса! Тасманы җәйләп кына, ашыкмый көйләп җибәрәсең дә, та-та-та-та!* И.Туктар

**ТАТАР** *и.* 1) Башлыча Татарстанда, шулай ук аерым Идел буе өлкәләрендә яши торган, нигездә ислам динендәге төрки халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Аның татар сүзләрен таба алмыйча гаҗиз булуы сизелә иде.* А.Тимергалин. *Татар әбиләре генә шулай пөхтә, матур итеп, иң мөһиме: актан киенеп йөриләр.* Г.Гыйльманов

2) *җый.* Татар халкы, татарлар. *Рабига апаларның Яңа бистәдәге өйләренә институтта укыган елларымда татарда иң затлы ризыклардан саналган әлбә ашарга барып йөри идем.* А.Хәсәнов. *Бу – Казанның гына түгел, бөтен татар дөньясының аң-белем үзәге һәм олуг серләр сандыгы саналган институт.* Ф.Яхин

3) *диал.* Ир кеше, ир-ат. *– Ай-яй, оста татар икәнсең, – диде түтәй, – көн саен сиңа күкәй чәчәрләр, көн саен күкәй ашатырлар – эчеңә тияр.* Ш.Маннур

4) *диал.* Өйләнгән ир кеше, хатынлы ир. *Татарым үземнән биш яшькә олырак*

5) *иск.* Кырым, Кавказ якларында яшәүче кайбер мөселман төрки кабиләләрнең я этник төркемнәрнең уртак атамасы. *Көнбатыш Себердә яшәүче җирле себер татарлары һәм күчеп утырган татарларның этник яктан якынаю алшартлары шулай ук, миграция хәрәкәте нәтиҗәсендә, бу төбәктә Идел-Урал татарларының төпләнеп калуларына бәйле.* Д.Исхаков

6) *иск.* Себердә яшәгән хакас, шор кебек кайбер халыкларның элекке атамасы

7) *тар.* Борынгы заманнарда Көнчыгыш Себердә, Монголиядә һәм Кытайда яшәгән, монгол, маньчжур телләрендә сөйләшкән кайбер кабиләләрнең гомуми исеме

**ТАТА́Р АТНАСЫ** *и. диал.* Җомга (керәшен сөйләшләрендә). *Әлбәдендә атна арасындагы көн исемнәре дә базарлар белән бәйләнешле: атна арты, Питрәч базары, Казы базары, кече атна, татар атнасы, мунча киче, атна көн.* Н.Максимов

**ТАТАР-БАШКОРТ** *җый. и.* Татарлар һәм башкортлар (бергә алганда). *Мин БДУда шигърият йолдызларының берсе идем, бөтен Уфа, һичьюгы татар-башкорт даирәсе, мине беләдер, яратадыр сыман иде.* М.Кәбиров

**ТАТАРЛА́РЧА** *рәв.* Татарларга хас булганча, татарларга охшатып. *Чакырылмаган кунакны Тиңләсеннәр татарга. Татарларча кунакчыл без Дусларга һәм ятларга.* Мөҗәһит

**ТАТАРЛАШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **татарлашу**. *Хәтта зур дәрәҗәле кайбер галимнәребез, безнең милләтнең исеме борын-борыннан татар булган, алар, Үзәк Азиядән монгол-татар яулары белән килеп, Идел буендагы болгарларны басып алганнар, татарлаштырганнар, дип лаф ордылар.* Ә.Кәримуллин

2) Татар милли үзенчәлекләрен кертү, татарча итү; татар җирлегенә туры китерү. *Ул [Бәхтияров] әүвәл русско-татарская школаны үз кулыннан килгән кадәр татарлаштыра.* Ф.Әмирхан. *Без чит илдә, Россиядә нинди кызыклы проектлар бар, шуларны татарлаштырырга тырышабыз.* Идел

**Татарлаштыра бару** Һәммәсен эзлекле рәвештә татарлаштыру

**Татарлаштыра төшү** Берникадәр татарлаштыру; тагын да татарлаштыру

**Татарлаштырып бетерү** Барысын да татарлаштыру; тулысынча татарлаштыру. *Гомумән, компьютерга нисбәтле меңләгән (!) терминны татарлаштырып бетерү мөмкин түгел, мондый шөгыльнең перспективасы юк, кирәге дә юк.* А.Тимергалин

**Татарлаштырып тору** Әле, хәзер татарлаштыру

**ТАТАРЛАШУ** *ф.* Татарга әверелү, татар булып китү; татар телен, мәдәниятен үзенеке итеп таный башлау. *Йөз еллар буенча рус сүзләре безнең телебезгә гел кереп килгән, аларның бик күбесе хәзер шул дәрәҗәдә татарлашкан, үзгәргән: үз сүзебез булып киткән ---.* И.Гази. *Ләкин X гасырның ахырында болгарларның төп өлеше Көнчыгыш Европага күчеп китә, калганнары татарлаша.* И.Хуҗин

**Татарлаша бару** Торган саен күбрәк татарлашу. *Без XIV–XVI йөзләрдә урыс документларында бисермән дип аталган этник төркемне Болгар олысы чорларында мөселман диненә кергән һәм татарлаша барган угорлар белән тәңгәлләштерү ягында торабыз.* М.Әхмәтҗанов

**Татарлаша төшү** Берникадәр татарлашу; тагын да ныграк татарлашу. *Карагашлар, нугай теленең үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, шактый гына татарлаша төшә...* Д.Исхаков

**Татарлашып бетү** Бик нык, тулысынча татарлашу. *Хәтта, артка кайтып, әллә кайчан татарлашып беткән сүзләрне киредән русчага әйләндереп язу кагыйдәләре кертелде.* И.Гази. *Ләкин юрматылар XIV гасыр уртасына татарлашып бетеп, соңыннан Нугай урдасын төзүчеләрнең берсе булып китәләр.* М.Әхмәтҗанов

**Татарлашып килү** Соңгы вакытка таба акрынлап татарлашу. *Матур гына татарлашып килгән мәктәп-гимназияләребез күзгә күренеп артка таба тәгәри.* Б.Рәхимова

**Татарлашып китү** Билгеле бер вакыттан алып татарлашу. *Революциядән соң да рус сүзләре, рус теле аша чит ил сүзләре телебезгә бик күп керде, һәм ул сүзләрнең күбесе бөтенләй татарлашып китте.* И.Гази. *Бу авыл халкының элек чуваштан, чирмештән, ардан яки мукшыдан булып та, соңыннан мөселманлык кабул итеп татарлашып китүләре турында хәбәрләр юкмы?* Г.Рәхим

**ТАТАРЛЫК** *и.* 1) Татар булу үзлеге. *Аларның чигүле тышлыклары шулкадәр дә күзне иркәләп тора: кайдадыр җан түрендә татарлыгым өчен*

*горурлык хисе баш калкытып куйды.* Г.Гыйльманов

2) Татарларга хас булган нинди дә булса берәр сыйфат яисә сыйфатлар. *Ләкин, әфәндем, сез татарлык белән юкка булашасыз.* Г.Толымбай. *Менә ул гомер буе баш иеп, бил бөгеп йөрүгә әверелгән татарлык галәмәте!* В.Имамов

3) *җый. и.* Татар халкының милли-мәдәни һәм матди мирасы; татарның милли үзенчәлекләре. *Аның [Әхмәтнең] әсәрләр язудан төп максуды – борынгы татарлыкны терелтеп, ничә йөз еллар үткән бабайларның тормышын күрсәтү иде.* Г.Газиз

**ТАТА́РЧА** *рәв.* **1.** 1) Татар телендә. *Чөнки мең ярым ел эчендә милләтне саклаган менә шушы әбиләрнең татарча әйткән дога-теләкләре бара Ходай Тәгаләгә!* Н.Кәримова

2) Татар халкындагыча. *Тәрәзә пәрдәләре, өстәл җәймәләре, ашъяулык, чыбылдыклар да чын татарча тегелгән, бизәлгән, чигелгән иде.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Татар телендәге. *Балалар йортында чакта һәр бәйрәмдә аңардан татарча шигырь сөйләттерәләр иде.* Г.Гыйльманов

2) Татар халкына караган, шуңа хас булганча. *Анда руслар өчен русча, татарлар өчен татарча көйгә гармун уйнап баручылар да бар.* Н.Яһудин. *Милли дигәннән, ә менә үзебезнең чын милли, татарча туй ничегрәк үтәр иде икән?!* Кәеф ничек?

**3.** *и. мәгъ.* Татар теле. *Бу – Рәхимовларның кечкенә балаларын яңа ысул белән татарча укытучы мөгаллим, һәр көнне шушы вакытта балаларга сабак бирергә килә иде.* Ф.Әмирхан. *Татарчасы бик яхшы түгел*

**ТАТА́РЧАЛАП** *рәв.* 1) Татар телендә. *Бу яктан да татарча, дивар-манарадан да татарчалап кычкыралар.* Р.Батулла. *Сүзсез генә басып торган кызына тагын татарчалап дәште ---.* З.Зәйнуллин

2) Татарларда булганча, татарларга охшатып. *Оят булса да әйтим: репетицияләр башланганда, мин әле татарчалап яулык та бәйли белми идем.* Р.Вәлиев. *Эчеп калыйк әле чәйне, энем, бүген, Татарчалап: җиләк, бал салып.* М.Гайфуллина

**ТАТА́РЧАЛАТЫП** *рәв. гади с.* 1) Махсус рәвештә саф татар телендә, саф татарча (башка телгә каршы куеп). *Хәят та күзләрен елмайтты һәм татарчалатып: – Кич юк! Без... – дип, әллә нәрсә әйтә башлады.* Ф.Әмирхан. *Атасы доганы, Габдулла да аңласын дигәндәй, татарчалатып әйтеп бирде ---.* Р.Батулла

2) Татар теленә тәрҗемә итеп. *Плиталарның сул ягына урысча, уң ягына татарчалатып, һәлак булган сугышчыларга – безнең әтиләргә багышланган хат-васыятьнамә төзедем.* Ш.Мостафин. *Профсоюзлар, ягъни, татарчалатып әйткәндә, һөнәри берлекләр, ул көнне, гадәттәгечә, митинг-концертлар уздырырга әзерләнә.* Безнең гәҗит

**ТАТА́РЧАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Татарчага, татар теленә тәрҗемә итү. *М.Максуд татарчалаштырган китапларның исемлеге озын.* М.Хуҗин. *Казанда, Уфада, Ырынбурда кыргыз, үзбәк, аеруча казак дастаннарының берникадәр татарчалаштырылган дистәләгән версия-вариантлары дөнья күрә.* Ф.Урманче

2) Татар теленең үз төзелешенә, системасына якынлаштыру, үзләштерү. *Ул гына да түгел, журнал битләрендә Гогольнең «Старосветские помещики» хикәясе – Исхакый персонажларның исемнәрен татарчалаштырып тәрҗемә иткән әсәре урнаштырыла.* Т.Галиуллин. --- *шактый аббревиатуралар телнең үз материалында, ягъни татарчалаштырылган сүзтезмәләрне кыскарту юлы белән ясалган.* Р.Мөхиярова

**Татарчалаштыра бару** Барысын эзлекле рәвештә татарчалаштыру

**Татарчалаштыра башлау** Татарчалаштырырга тотыну. *Аннан да элегрәк язучы А.Шамов «Тар-мар»ны («Разгром») татарчалаштыра башлаган иде.* Р.Фәйзуллин

**Татарчалаштырып бетерү** Тулысынча татарчалаштыру; барысын да татарчалаштыру. *Фабарисов Мәрьямбанудан барысын да көтте: техникумын гына түгел, бөтен шәһәрне татарчалаштырып бетерүен дә, җитәкчеләргә каршы митинг-пикет оештыруларын да, үзе кебекләрне ияртеп, хәтта хакимияткә килү мөмкинлеген дә!* Ф.Бәйрәмова

**Татарчалаштырып тору** Әле, хәзер татарчалаштыру; даими, булган берсен татарчалаштыру

**Татарчалаштырып утыру** *сөйл. к.* **татарчалаштырып тору**. *Берничә еллар элек бездә рус сүзләрен татарчалаштыру процессы барган булса, хәзер радионың да, телевидениенең дә, журналистларның да, язучыларның да артык татарчалаштырып утырасы килми кебек тоела.* Ф.Сафиуллина

**ТАТА́РЧАЛЫК** *и.* 1) Татарча булу, татар теленә, мәдәниятенә хас сыйфатлар, үзенчәлекләр. *Алынмаларны фонетик билгеләр буенча тану өчен, барча югарыда телгә алынган татарчалык үзенчәлекләрен истә тоту кирәк.* Р.Әхмәтьянов. *Баянның яңгырашында ук, ничектер, татарлык, татарчалык сизелеп тора.* Р.Миңнуллин

2) Татар акценты. *Солдат ни өчендер дулкынлана, һәм аның сөйләвендә татарчалык нык сизелә иде.* Н.Дәүли

**ТАТАРЧЫ** *и.* 1) Татарчылык (*1 мәгъ.*) тарафдары. *1910 елларга татарчылар, ягъни әдәби телне татар теленең нигезе итәргә теләүчеләр җиңеп чыгалар.* Д.Исхаков

2) Татарчылык (*2 мәгъ.*) тарафдары. *Мин – Болгарны өйрәнүче галим, әмма болгарчы түгелмен: халкыбызның килеп чыгышын болгарлар белән генә бәйләмим. Әмма мин татарчы да түгел.* Р.Юныс

**ТАТАРЧЫЛЫК** *и.* 1) XX гасыр башында, төрекчелеккә капма-каршы буларак, Казан татарлары телен әдәби тел нигезе итеп алуны, шуны үстерү, укыту теле итү фикерен алга сөргән иҗтимагый агым. *Милләтчеләр әле татарчылык, туранчылык идеяләре белән буталалар.* Г.Нигъмәти. *Галим инкыйлаб вә реакция көрәшендә телдә ике агым – төрекчелек һәм татарчылык агымнарының көрәшен билгеләп уза.* Т.Гыйләҗев

2) Болгарчылыкка капма-каршы буларак, татар халкының этнос булып формалашуын Алтын Урда чорында монгол-татарлар, җирле болгарлар һәм кыпчаклар синтезы итеп карау яклы

булган иҗтимагый агым. *Татарчылык юнәлешенә килсәк, ул да, бүген безгә тоелганча, гади реалистик тарихи концепция түгел, бәлки шактый катлаулы һәм каршылыклы юнәлеш иде ---.* Казан утлары. *Бу алым укучыларда туган телгә, мәдәниятә, әдәбиятка мәхәббәт уята һәм татарчылык концепциясен тормышка ашырырга да ярдәм итә.* Фән һәм тел

**ТАТЛАНДЫРГЫЧ** *и.* Татлы итә торган матдә, тәмләткеч. *Бу татландыргычларның калориясе аз*

**ТАТЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Татлы итү. *– Күзләрең якты синең, Айдаш, – диде һәм егетнең иреннәрен татландырып үпте дә, сикереп торып, өйгә таба йөгерде.* М.Хуҗин

2) *күч.* Сүзне матурайту, күңелгә, колакка ятышлы, кабул итәргә җиңелрәк итү. *Вагыйз: «Әр-рижалү кавамун галяин-ниса», – дип башлады һәм шул фикерне балландырып, татландырып сөйләргә керешә.* Г.Исхакый

**Татландыра төшү** Тагын да берникадәр татландыру

**Татландырып бетерү** Бик татландыру

**Татландырып җибәрү** Кинәт яки бераз татландыру. *Әче дигән мизгелләрне Татландырып җибәрче!* Ф.Дәүләтгәрәева

**ТАТЛАНУ** *ф. к.* **татлылану**. *Мәхәббәттән сукырлар күзле. Аксаклар аякланган; Хыяллар, дәрт вә михнәтләр, Газаплар – бар да татланган.* Н.Думави

**Татлана бару** Торган саен ныграк татлану

**Татлана төшү** Тагын да берникадәр татлану

**Татланып алу** Азга гына татлану

**Татланып китү** Кинәт кенә татлану

**Татланып кую** Азга гына татлану

**ТАТЛА́У** *ф.* 1) Кабып тәмен белү

2) *күч.* Рәхәтен белү. *Тормышның тәмен тәмләп, татын татлап яшәделәр.* Г.Исхакый

**ТАТЛЫ** *с.* **1.** 1) Үзендә шикәр һәм бал тәме булган, баллы. *Кичә уздыралар, дус-ишләрен сыйлыйлар, тәмле-тәмле ашамлыклар ашыйлар, балдан татлы эчемлекләр эчәләр, ду килеп биилә р.* А.Алиш. *Авызга әчкелтем-баллы гаҗәеп татлы җиләк тәме таралды.* Ф.Хуҗин

2) Тәмле, тәме күңелгә хуш килгән. *Каз үзенең бәпкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыслалар тотып китерә икән.* А.Алиш

3) *күч.* Ләззәт, кинәнеч һәм рәхәтлек хисе бирә торган. *Шундый татлы хыялларга чумып торганда гына, олы юл буйлап зур тизлектә җилдергән «Приора» пәйда булды.* Ф.Хуҗин. *Иртәнге йокы татлы була бит.* Г.Гыйльманов

4) Шундый хисләр чагылган. *Ир кешенең йөзендә татлы елмаю чагылды.* З.Мурсиев

5) *күч.* Берәр кешегә ошый торган; күңел кабул итә торган. *Кошны җим белән, кешене татлы сүз белән ияләштерәләр.* Мәкаль. *Бу хәлдә хәйлә дә, татлы ялган да ярдәм итмәячәк.* М.Әмирханов

6) *күч.* Кадерле, ягымлы, сөйкемле, күңелгә якын. *Бал татлы, балдан бала татлы.* Мәкаль. *Балдан татлы бала син, Айдан якты бала син.* Н.Әхмәдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Ләззәтле итеп, рәхәтләнеп, кинәнеп; рәхәт, ләззәтле уйларга бирелеп; матур итеп. *Әллә шуңа күрә инде моңы-сагышы, шиге-өмете, кайгысы-шатлыгы – барысы бергә күңелне татлы итеп сызландыра.* Г.Әпсәләмов. *Сездәй затлы кешенең татлы итеп сөйләгәнен тыңларга үлепләр яратам мин!* Л.Лерон

**3.** *и. мәгъ.* 1) *кул.* Десерт. *Татар семьяларында чәй янына татлы – бик хуш исле баллы помада куела.* Татар халык ашлары

2) Баллы, тәмле ризык. *Алдында кренделе, шәһәр калачы, шикәре, конфеты, татлысы һәм баллысы, мае, кайнатмасы мул итеп өелгән һәм тезелгән.* Ф.Яхин. *Шатлык бик аз булганга шатлык дип атала, бәхет тә бик кыска булганга бәхет дип атала, татлы бик аз эләккәнгә, бик тәмле була, бәхет дигәнең көтмәгәндә ничек килсә, шулай китеп тә бара.* З.Кадыйрова

◊ **Татлы җидереп, ачы костыру** Башта бик йомшак мөгамәлә күрсәтеп, кунакчыллык күрсәтеп, соңыннан авыр сүз әйтү, начарлык эшләү

**ТАТЛЫБӘРӘҢГЕ** *и. бот.* Уралмасабаклылар семьялыгыннан бүлбеле үсемлек һәм шуның ашарга яраклы бүлбесе; батат. *Һәр җирдә диярлек татлы бәрәңге үстерәләр.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТАТЛЫКУЗАК** *и. бот.* Баллыкузак. *Рәхәтләнеп татлыкузак җыеп яткан-да, бер дә көтмәгәндә, әллә кайдан бригадир Шәфигулла килеп чыкмасынмы?* И.Диндаров

**ТАТЛЫЛАНДЫРГЫЧ** *и. ялг. к.* **татландыргыч**

**ТАТЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Татлы (*1 мәгъ.*) булып китү; татлыга әверелү. *Җәй көне һәм көз башында аның өчен азык мул була: җиләк-җимеш өлгерә, үсемлек тамырлары татлылана һәм сусыллана, исәпсез-хисапсыз бөҗәкләр оча (аю кырмыскаларны гаҗәп ярата, кыргый умарта корты һәм шөпшә балын бик тәмләп ашый, солы бөртекләрен дә суыра).* Көмеш кыңгырау. **–** *Кишерне әле бераз алмый торсаң да була, алай бу файдалы тамыразык татлылана гына, – дип искәртә танылган бакчачы.* Хезмәт даны

2) *күч.* Ягымлылану (сүз, сөйләшү тур.)

**Татлылана бару** Торган саен тагын да татлылану. *Ни булыр, белмим, һаман татлылана бара, шайтан алгыры!* Х.Камалов

**Татлылана төшү** Берникадәр татлылану; тагын да татлылану

**Татлыланып җитү** Бик татлылану; тиешле дәрәҗәдә татлылану. *Инҗир, пешеп вә татлыланып җиткәч, ярыладыр ---.* К.Насыйри

**Татлыланып китү** Кинәт татлылану. *Телефонда сөйләшүченең кырыс тавышы кинәт үзгәреп, татлыланып китте.* М.Әмир

**Татлыланып кую** Кинәт, азга гына татлылану

**Татлыланып тору** Әле, хәзерге вакытта татлылану; даими яки әледән-әле татлылану

**ТАТЛЫТАМАК** *и. к.* **тәмлетамак**. *Яшь чагында бик татлытамак булгансың, ахрысы, түтәй.* Г.Әпсәләмов. *Ул татлытамактан умарталыкны яхшылап сакларга кирәк.* А.Гадел

**ТАТЛЫТАМЫР** *и. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан каурыйсыман яфраклы, ал чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **лакрица**. *Нигә таулар мендем икән Бер татлытамыр өчен; Нигә ярлар сөйдем икән Озатып калыр өчен.* Җыр

2) Шул үсемлекнең тамырын киптереп, порошок хәленә китерелгән һәм эч кату һ.б. авырулардан кулланыла торган дару. *Майтүтәй, --- әнәйне терелтер өчен, эмбер тамыры, татлытамыр, тәмле сабыр дигән дарулар да эчереп карады.* Ш.Маннур

3) Шикәр чөгендере. *Күп алдыгызмы соң татлытамырны?* А.Гыйләҗев. *Ел йомгаклары буенча шикәр чөгендере иң табышлы культура булды. Барлыгы 51,1 мең тонна татлытамыр казылды.* Р.Баһаветдинов

**ТАТЛЫ́-ТАТЛЫ** *с.* Берсе берсеннән татлы, барысы да татлы булган. *Бирәдә иреннәрең кебек тәмле-тәмле, татлы-татлы ризыклар сатылачак.* Н.Гыйматдинова

**ТАТЛЫТЕЛ** *и. к.* **тәмлетел**. *– Сайлап кына, чүпләп кенә кунак җыябыз, шәмгә ут алуга килеп җитегез, – диде тыкрык буе татлытел Вәлетдин, иртүк килеп.* М.Кәрим

**ТАТЛЫТЕЛЛЕ** *с.* Кешеләрнең күңеленә хуш килерлек итеп, куштанланып сөйли белгән. *Чапкыным сүзләренә ышансак, Сафура бикә күз алмастай чибәр, горур, татлытелле икән.* М.Хәбибуллин. *Дәртсенеп укып йөргән татлытелле агрономмы?* А.Гыйләҗев

**ТАТЛЫТЕЛЛЕЛЕК** *и.* Кешеләрнең күңеленә хуш килерлек итеп сөйләү осталыгы, куштанланып сөйләү сыйфаты; тәмлетеллелек

**ТАТЛЫТОРМА** *и. бот.* Гәрәнкә

**ТАТЛЫЧИЯ** *и. бот. к.* **төчечия**. *Италиядә алма, груша, шәфталу, абрикос, татлычия, инҗир кебек төрле-төрле җиләк-җимешләр үстерелгәнгә күрә, аны Европаның төп бакчасы дип атыйлар.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Кайбер язучыларның бакчаларында да безнең татлычия хәзер дә әле үсеп утыра торгандыр.* Ә.Еники

**ТАТСЫЗ** *с.* 1) Тәмсез, татлы түгел. *Татсыз шулпага тоз файда итмәс.* Мәкаль. *Әнә элек зәмзәм булган Суы бүген үзгәргән: Тәме татсыз, әллә өстән, Әллә төптән – тирәннән.* К.Булатова

2) *күч.* Авыр, газаплы, рәхәте булмаган. *Котылмакчы булып татсыз хәяттан, Гакыл бу, дип, үзеңне үзең үтердең.* Г.Тукай

**ТАТСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Тәмсезләнү, татлы тәм бетү, киму

2) *күч.* Рәте китү, кызыгы бетү, авыр, газаплы булып китү

**Татсызланып бетү** Бик татсызлану

**ТАТСЫЗЛЫК** *и.* 1) Тәмсезлек, тәмле булмау, татсыз булу. *Болар арасындагы уртаклык, охшашлык – тәмсезлек, татсызлык.* Г.Әхәтов

2) *күч.* Күңелсезлек, кызыксызлык, рәхәтсезлек; авырлык

**ТАТУ** I *рәв.* **1.** Үзара килешеп; дусларча; ызгыш-талашсыз. *Алар, ут күршеләр булып, бүген дә булса бик тату яшәп яталар.* А.Хәлим. *Моңарчы тату гына гомер кичергән сыерчыклар гаиләсендә чын мәхшәр көннәр менә хәзер башлана.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Татулыкка корылган, дус. *Мондый тынлык бердәм һәм тату семья үзенең сөекле бер кешесен ерак, җаваплы юлга озатып калганнан соң була.* Г.Әпсәләмов. *Тагын бер үзенчәлекле як: җәйге иртәләрдә монда өй кәрнизләренә тезелгән күгәрченнәрнең искиткеч тату гөрләшүләре ишетелеп тора...* Ф.Хөсни

**ТАТУ** II *ф.* 1) Ашамлык-эчемлек, дару кебек нәрсәләрнең бик азын гына кабып карау; авыз итү. *Шикәр белән чәйнәлгән арыш ипиенең тәмен дә бирәдә татыганбыз.* М.Садыйков. *Ә «Мокко»ны гади халык белеп бетермәсә дә, җаваплы урында эшләгән «халык дошманнары»ның балалары белә, чөнки сирәк-мирәк татып караганнар...* А.Тимергалин

2) Нәрсәнең дә булса тәме икенче бер әйбердә сизелү. *Суырып үпсәм, авызы баллар татыр.* Г.Тукай

3) Берәр ашамлык-эчемлек яки агударуның тәмен сынау. *Ир, татымам, дигән тозны өч татыр.* Мәкаль

4) *күч.* Берәр хәлнең, хис-кичерешнең рәхәтлеген яки кыенлыгын баштан кичерү, кичереп белү. *Әнә шул чын тормышның тәмен татыйсым килә!* М.Вәлиев. *Тыныч яшәү бәхетен дөньялыкта азлар, бик азлар гына татый.* Ф.Яхин

**Татый башлау** Татырга тотыну. *Әткәй, син күргән газапларны улың да татый башлады.* А.Алиш. *Алар тормышның катлаулы авырлыгын үз җилкәләрендә әнә шулай татый башлады.* Р.Батулла

**Татый бирү** Бернигә карамый тату; һаман да тату. *Кыз җиде кат күкләрнең рәхәтен татый бирде.* Ф.Яхин

**Татый тору** Әледән-әле тату. *Кергәне берсе, минем өлештән бармак очы кадәр генә кисеп алып, кавын тәмен татый торгач, күчтәнәч юкка чыккан.* М.Юныс

**Татып алу** Тиз арада тату

**Татып бару** Даими тату. *Юлында нинди җан иясе очраса, шуны чагып, канын татып барды.* А.Нәҗми

**Татып бетерү** Тулысынча тату; бик нык тату. *– Әмма яшьләр дөньяның күп тугрыда тәгамен татып бетергәннәре юк, – диде.* К.Насыйри

**Татып калу** Татырга өлгерү. *Бер картлыкта, бер яшьлектә, дигәндәй, дөньяның тәмен татып калыйк.* Ф.Яруллин. *Ашыга ул, барысын да татып калмам диеп курка.* А.Нәҗми

**Татып килү** Күптәннән бирле тату. *Әллә безнең халык күптән үк ачы михнәтләр генә татып килгән дә шунлыктан чын шатлык белән шатлана алмыймы?* Г.Рәхим

**Татып кую** Көтмәгәндә тату; бераз тату. *Тормышның ямен-тәмен тагын бер мәртәбә татып куйгандай буласың.* А.Хәсәнов

**Татып тору** Әле, хәзерге вакытта тату; даими яки әледән-әле тату

**Татып чыгу** Барысы да бер-бер артлы тату. *Бөтен өйдәгеләр шулпадан татып чыккач, һәммәсе рәтләнеп утырып дога кылдылар.* Г.Ибраһимов

**ТАТУ** III *и. ингл. к.* **татуировка**. *Тәләгегез булса, пирсингтан тыш, тату, шрам, татуаж да ясый алалар.* Ватаным Татарстан

**ТАТУАЖ** *и. фр.* 1) Биттәге кайбер төгәлсезлекләрне төзәтү, матурлыкны калкурак итү йөзеннән, махсус каралар белән сызыклар сызу. *Су коенганда*

*уңайсыз хәлдә калудан, иртән сөеклесе алдында ямьсез күренүдән курыкканнар перманент макияжга (татуаж) мөрәҗәгать итә.* Кәеф ничек? *Кызымның кашларына һәм иреннәренә татуаж ясатасы килә.* Яшел Үзән

2) *к.* **татуировка**

**ТАТУИРО́ВКА** *и. полинез.* 1) Тире катламына төрле төстәге кара сеңдереп ясалган язу, сурәт, рәсем. *Шулар арасыннан ул ике беләгенә дә бай татуировка – берсенә сине йотарга әзер юлбарыс, икенчесенә сине буарга әзер анаконда сурәтләре төшкәнен сайлады.* А.Хәсәнов. *Соры кримплен костюм җиңе тартылып киткәндә, кулындагы татуировкасы күзгә бәрелә.* Т.Әйди

2) Шундый рәсем ясау эше

**ТАТУЛАНДЫРУ** *ф. ялг. к.* **татулаштыру**. *Хәтта Сәфәр абыйсы белән шушы хакта бәхәс ачып кызып киткән чакларында, Суфия апа гына арага кереп татуландырган иде бер үзләрен.* Д.Зөбәерова

**ТАТУЛАНУ** *ф. ялг. к.* **татулашу**. *Ләкин, ни хикмәттер, минем Вәлиулла әти белән Шәриф агай әлеге шул ачуланышуларыннан соң татуланмыйлар гына түгел, киресенчә, бер-берсен күралмаулары отыры арта.* В.Нуруллин. *Татуланыгыз, кардәшләрем, тамыры корысын көнчелектән туган гауганың!* Р.Батулла

**ТАТУЛА́У** *ф.* 1) *ялг. к.* **татулаштыру**

2) *сөйл.* Ачуын, үпкәсен бетерү; тынычландыру. *Госман әфәнде, сез чынлап та Зәйнәп ханымны татуласагыз ла.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Татулап тору** Әле, хәзерге вакытта татулау; даими яки әледән-әле татулау

**ТАТУЛАШТЫРУ** *ф.* Дуслаштыру, килештерү. *Үзара дошманлашып йөргән югары оч һәм түбән оч малайларын буа татулаштырды, бөтенесе дә кым-кырыч онытылып эшләделәр...* А.Гыйләҗев. *Ә минә журналистлар халыклар белән халыкларны дуслаштыра, татулаштыра ала.* Безнең гәҗит

**Татулаштыра килү** Күптәннән бирле эзлекле рәвештә татулаштыру. *Малай булу гаиләдәге мондый күңелсезлекләрне тиз оныттыра, өчесен дә татулаштыра, килештерә килде.* Ф.Садриев

**Татулаштырып бетерү** Барысын да татулаштыру

**Татулаштырып кую** Тиз арада татулаштыру

**Татулаштырып тору** Даими татулаштыру; хәзер татулаштыру. *Мин, «Сельхозхимия»дә эшләгәндә дә, аны ире белән гел татулаштырып тора идем.* Безнең гәҗит

**ТАТУЛАШУ** *ф.* Нинди дә булса низаг, кычкырыш-талаштан соң яңадан килешеп, тату, дус булып китү. *Кояш Яңгыр белән күп кычкырышкач, Берберсен яманларга тырышкач, – Татулашты, килештеләр ахырда, Бу көннән сүз көрәштермәскә бер дә.* Г.Тукай. *Шул көнне безнең арбага төялешеп кайткач, Зәңгәр чишмәдә бик озак су кердек тә, татулашып, дуслашып тарадык...* Г.Ибраһимов

**Татулаша бару** Акрынлап татулашу, торган саен күбрәк татулашу

**Татулаша төшү** Берникадәр татулашу. *Бераздан без, татулаша төшеп һәм өчебез бер баш булып, туган авылыбызга үпкә-зар түгә башладык ---.* Э.Касыймов

**Татулашып алу** Азга гына татулашу; тиз арада татулашу. *Шул ук вакытта Олуг Мөхәммәт Урта Азия белән – Аксак Тимернең улы Шаһрух белән дә татулашып ала.* Р.Фәхретдинов. *Беркөнне эчеп сугышсалар, икенче көнне татулашып алалар.* С.Поварисов

**Татулашып бетү** Тәмам татулашу

**Татулашып кую** Тиз арада яки көтмәгәндә татулашу. *Уларының татулашып куюларына Чыңгыз үзе дә сөенә.* А.Хәсәнов

**Татулашып китү** *к.* **татулашып кую**. *Агасике һәрчак базилевстан курку тойды. Яшерен илчесе Агасикенең Кубрат хан белән татулашып китүен сизсә, базилевс аны кичермәс.* М.Хәбибуллин. *Хәер, бәлкем әле татулашып китәрләр, Кәшшаф та акылына килер ---.* М.Әмирханов

**Татулашып тору** Әле, хәзер татулашу; вакытлыча татулашу; даими яки әледән-әле татулашу. *Рамазан аенда вакытлыча татулашып торырга әзер булганын белдергән хәбәр әлегә Сүриядән генә килде.* Шәһри Казан

**ТАТУЛЫК** *и.* Тату булу, дуслык, бердәмлек. *Ике арада татулык, аңлашу юк икән, нәрсә соң ул акча?!* А.Гыйләҗев. *Максат милләтләр арасында дуслык, татулык, туганлык тәрбияләү ләбаса!* А.Хәсәнов

**ТАТУСЫЗ** *рәв.* **1.** Ызгышып-талашып; ызгыш-талаш белән. *Татусыз яшәү*

**2.** *с. мәгъ.* Ызгышлы, талашлы, татулык булмаган. *Татусыз гаилә тормышы*

**ТАТУСЫЗЛЫК** *и.* Дус булмау, ызгыш-талаш; тынычсызлык. *Өйдәге татусызлык корыч холыклы адәмне дә тетрәндерә.* Б.Камалов. *Патшаларның татусызлыгы әллә кемнәр белән таныштырыр.* Безнең мирас

**ТАТЫЛДА́У** *ф. сөйл.* 1) Тиз-тиз, ашыгып сөйләп тору; бик күп сөйләү. *Татылдарга маһирланып киттең әле син, кара карлыгачым.* Т.Галиуллин

2) Бытылдау (бала тур.) *Җитмәсә, бала бертуктамый татылдый, боргалана.* И.Нәбиуллина

3) Та-та-та иткән тавышлар чыгару. *Һавада пулемётлар татылдады, ике самолёт, бастырышып, бер югары үрләде, бер, уктай, аска ташланды.* Ә.Хәкимов

**Татылдап алу** Бераз татылдау

**Татылдап кую** Аз гына татылдау; кыска гына татылдау

**Татылдый башлау** Татылдарга тотыну. *Шамил әнисен муеныннан урап кысып кочаклап ала да, бер-ике минуттан җибәреп, тагын бөтерелә, татылдый башлый.* И.Нәбиуллина

**Татылдый бирү** Берничә карамый татылдау; һаман татылдау. *Сәрбиямал карчык татылдый бирде, Шәрифә дәшмәде.* Казан утлары

**ТАТЫЛДЫК** *с.* **1.** Күп сөйләүчән. *Татылдык хатын*

**2.** *и. мәгъ.* Күп сөйләүчән кеше. *Татылдыкка тышау юк.* Мәкаль

**ТАТЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **тату** II. *Никадәр шатлык татылмаган да ничаклы сагыш кичерелмәгән!..* Р.Фәйзуллин. *Сине күрү белән, яз җилләре Битләремә килеп бәрелде. Моңа кадәр татылмаган бер наз Сыйпап үтте минем тәнемне.* Ф.Яруллин

**ТАТЫМ** *и.* **1.** 1) Татып караганда беленә торган тәм. *Бала – бал татым.* Мәкаль

2) *күч.* Зәвык. *Бу гади бер [әдәби] татым мәсьәләсе генә түгел.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* Татып караганда беленә торган. *Борынны кытыклап, бал татым хуш ис аңкый.* И.Салахов

◊ **Татымын алу** Тәмләп карау, авыз итү

**ТАТЫМЛЫ** *с.* 1) Тәме озакка бара, авызда озак сизелә торган

2) Ягымлы, татлы (*2 мәгъ.*). *Ул [Тимери] йөрәккә үтерлек татымлы сүзләр табарга тырышты.* Г.Бәширов

**ТАТЫМСЫЗ** *с.* 1) Тәмсез, тәме булмаган

2) *күч.* Асылы, үзенчәлеге, кызыгы булмаган. *Тозлыксыз өйрә татымсыз, кызлыксыз кәләш татымсыз.* Мәкаль

**ТАТЫР** *и. диал.* 1) Елга, чишмә суларында эрегән, ачы булмаган тоз. *Суның татыры сизелә*

2) *к.* **катыр** I. *Татыр, татырда мал ятыр.* Мәкаль

**ТАТЫРЛЫ** *с.* Составында кальций һәм калий тозлары күп булган, татыры сизелеп торган (су тур.). *Үзләренең коесы да бар инде югыйсә. Ләкин суы татырлы.* А.Хәлим

**ТА́У** I *и.* **1.** 1) Тирә-ягындагы җирдән биек чыгынты хасил итеп, күтәрелеп торган, еш кына түбәсенә таба тарая барган калкулык яки кыя. *Зәңгәр күккә башлары тигән таулар уң якта, шомлы кара урманнар сул якта, көмеш тавышлы чишмәләр, юл буйлап елан төсле боргалана-боргалана, чылтыр-чылтыр агып калдылар, ди.* А.Алиш. *Тауга менүнең үз хозурлыгы: атлаган саен манзара үзгәрә бара.* З.Мурсиев

2) *сөйл.* Үр, кашлак; битләү, сөзәклек. *Ак колын сөзәк тауга чабып менә.* М.Хуҗин. *Кышкы ак тынлыкта тау башында егет белән кыз чаңгыда басып торалар.* Р.Хәбибуллина

3) *күч.* Зур булып өелгән һәртөрле нәрсәләр өеме. *Эреле-ваклы бүрәнәләр, такта өемнәре; тау булып елга комы, чуерташ, бут ташы, арматура тимерләре; яңгырдан саклар өчен ышык ясалган лапасларда цемент мичкәләре, төрле машиналар тиздән бу урында гигант салыначагы турында сөйлиләр.* А.Алиш. *Безнең позицияләр алдында дошман үләксәләреннән таулар өелде, шартлатылган, яндырылган, җимертелгән немец танклары һәм үзйөрешле орудиеләрнең саны артканнан-арта барды.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ. сир.* Текә, үрле. *Хәтта ул [Габдулла] дәртенә сыеша алмый, таурак урыннарга юри менеп китә.* Ә.Фәйзи

◊ **Тау актару** Зур эшләр башкару. *Мәгәр ялгыз көе генә тау актарып булмый.* В.Имамов. **Тау астына тәгәрәү** Эш барып чыкмау, көткән нәтиҗәләргә ирешә алмау. *Тартасыз инде, эшегез һаман тау астына тәгәри.* А.Алиш. **Тау булып ишелү** Көтмәгәндә күп итеп зур көч тәэсир итү. *Шундый көчсезлек-мескенлек мизгелләре өстенә тау булып ишелгәндә, үзен тирес корты, бөҗәк, ком бөртеге итеп сизә ---.* Р.Сибат. *Галимә әбинең көтмәгәндә тау булып ишелеп төшкән шатлыктан зиһене таралып, башы әйләнеп китте.* Сөембикә. **Тау булып ябырылу** *к.* **тау булып ишелү**. **Тау булып җимерелү** *к.* **тау булып ишелү**. **Тау булып басу** Бик зур көч, какшамас ныклык белән каршы тору, саклау. *Егет кеше яуга каршы тау булып басар.* Мәкаль. *Тау булып бастык дошман каршына, Дошман өстенә тау булып аудык.* Р.Әхмәтҗанов. **Тау булып тору** *к.* **тау булып басу**. *Коллективтагы гаилә төшенчәсе дә мөһим: бер-берең өчен тау булып тора белергә кирәк.* Шәһри Казан. **Тау кадәр (кадәрле, кебек, хәтле, чаклы)** 1) Бик зур, массив. *Тау кадәр трактор, утлары белән авыл урамын тутырып, буран эченә кереп югалган гына иде, өстендәге карны кага-кага, чаттан улларының укытучысы килеп чыкты.* Г.Гыйльманов. *Хәмит абзый – таза кеше, тау кадәр корсагы булуга карамастан, куәтле-көчле түгел.* Ф.Яхин; 2) Артык күп, күләмле; санап, әйтеп бетергесез. *Өстеңә тау кадәр бурыч өеп китәсеме инде хәзер?* Ф.Җамалетдинова; 3) Бик зур; бик әһәмиятле. *Тау кадәр бу җаваплылыкны күтәрү беренче көннәрдә бик кыен булды.* Г.Бәширов; 4) Үтә гайрәтле, бик көчле. *Йөкче, гәрчә тәбәнәк кенә, кечкенә генә кеше булса да, мал вә җан тугрысында тау кадәр булып китте.* Г.Тукай. **Тауга каршы сикерү** Башкарып чыгу кыен булган берәр эшкә тотыну; үтәп чыгу бик шикле булган эшкә керешү. *Арыслан да тауга каршы сикермәс, дигәннәр борынгылар. Ә сез Гыймади абзагызны тауга каршы сикертмәкче буласыз.* И.Гази. **Таулар вәгъдә итү** Чамасыз күп, кыйммәтле, әһәмиятле нәрсәләр вәгъдә итү. *Әллә нинди таулар вәгъдә итмәс, башка бер-бер юлын табар, сөйләштерер, кызны үзенеке итәр.* Ф.Яхин. **Тауны талкан итү** Зур көч һәм гайрәт белән эшләү; искиткеч зур эшләр башкару. *Ир уртасы тауны талкан итәр*. Мәкаль. **Тауны тәгәрмәч итү** *к.* **тауны талкан итү**. *[Низамов:] Бу егетләр белән тауны тәгәрмәч итеп әйләндереп була.* Ф.Кәрим. **Тауны тауга бәрү** Зур гайрәт, көч, масштаб белән эш итү. *Синең шикелле егетләр һәммәсе тауны тауга бәреп эш итәләр*. Ф.Әмирхан

**ТА́У** II *и. диал.* 1) Рәхмәт әйтү

2) Тәбрик; игелек теләү

3) Тост. *Дустыкаем, әй, тау сиңа. Тустаган тулы бал сиңа!* Җыр

4) *иск.* Васыять. *Тау әйтеп калдыру*

**ТА́У БАЛАВЫЗЫ** *и.* Нефть җир өстенә чыгып куерудан барлыкка килгән сары, яшел, көрән төсләрдәге балавызсыман минерал; *русчасы:* **горный воск**

**ТА́У БОЛАНЫ** *и. к.* **марал**

**ТА́У БӨРКЕТЕ** *и.* 1) Карчыга кошлар семьялыгыннан тауларда, тау урманнарында оя корып яшәүче ерткыч кош; *русчасы:* **горный хохлатый орёл**. *Түбәннән аларга каршы сугышчан иптәшләре йөгереп менәләр, ә биектә, якты зәңгәр күктә, оясыннан куркытылган тау бөркете канат җәеп оча иде.* Г.Әпсәләмов. *Яшь алмас мәңге карга-чыпчык Тау бөркете корган ояда.* С.Якупова

2) *күч.* Батыр, кыю, куркусыз кеше. *Нишләп шулай озакладың, тау бөркетем?* Р.Сәгъди

**ТАУ́ДАЙ** *с.* **1.** 1) Тау шикелле, формасы белән тауны хәтерләтә торган

2) Зур, күп санда. *Син әзерләнәсең – һаман әз кебек, һаман алда таудай эш.* А.Алиш

**2.** *рәв. мәгъ.* Күп итеп. *Шуннан ары яңа хуҗа килде безгә, Таудай өеп алтын вәгъдә бирде безгә ---.* Г.Афзал

**ТА́У ҖИТЕНЕ** *и. к.* **асбест**. *Әйе, асбест шул, асбест – таш җепселле тау җитене бит ул.* Казан утлары

**ТА́У ИНЖЕНЕРЫ** *и.* Тау эшләре инженеры. *Тау инженеры мондый билгеләмә ясар: нефть – сыек халдәге файдалы казылма, ул җир астыннан һәрвакытта да диярлек скважиналар ярдәмендә чыгарыла.* Нефть турында хикәяләр

**ТА́У ИТҮ** *ф. иск. диал.* 1) Тәбрикләү. *Яңа елны тау итү*

2) Рәхмәт әйтү. *Бу өйләрнең сые күп булыр, Тау итиек тә китиек.* Җыр. *Өйрәтүчебезгә тау иттек.* Туганайлар

**ТА́У КӘҖӘСЕ** *и.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан тауларда яши торган йорт кәҗәсенекедәй мөгезле хайван. *Менә бу тәлинкәдә кыяга баскан тау кәҗәсе.* А.Тимергалин. *Аны хәзер тау кәҗәләре дә куып тотарлык түгел иде.* Г.Тарханова

**ТА́У КУЫШЫ** *и. к.* **тау тишеге**. *Ниндидер сихер, тылсым бар, ахры, бу тау куышы тирәсендә.* Г.Гыйльманов

**ТАУ-КЫЯ** *җый. и.* Таулар һәм кыялар, таулы ландшафт. *Әйдә, мин сиңа үз язмышымның бер кисәген бирәм, җиргә төшмичә, мәңге тау-кыя араларында очып йөрер өчен көч-егәрлек иңдерәм...* Г.Гыйльманов

**ТАУЛЫ** *с.* **1.** 1) Үзендә таулар, тау сыртлары булган; тау-чагыллы. *Кавказ – Кара һәм Каспий диңгезләре арасында яткан таулы төбәк.* А.Тимергалин

2) Таулар аша үткән, тауларга туры килгән. *Ибраһим паша түмәннәрне яр буенча Дунай тамагына чаклы алып барачак, Яхъя агайга Дубрава аша үтәсе таулы юллар кала.* В.Имамов

**2.** *и. мәгъ.* Таулы илдә, таулыкта, таулар арасында яшәүче яки шундый яклардан чыккан кеше. *Хәкимзадә, сикереп, уртага килеп төшә: авызына пычак кабып, кулларын канат кебек җәеп, таулылар биюен башкара.* Г.Ахунов

**ТАУЛЫК** I *и.* 1) Таулы урын, таулардан торган җир. *Карадылар: торган җирләре таулык, ташлык арасы, чокыр җирдер.* К.Насыйри

2) Тау башы, калку җир. *Донецк таулыгында ул [туфрак ясаучы] токымда комташ, известьташ һәм балчык сланецының кисәкчекләре күренә.* А.Фәтхуллин

**ТАУЛЫК** II *и. диал.* Игеннең башта сынау өчен урып алына һәм сугыла торган өлеше. *Каршыдагы бораемның урып алдым таулыгын.* М.Фәйзи

**ТАУЛЫКЛЫ** *с.* Үзендә таулыклар булган

**ТАУЛЫ́-ТАШЛЫ** *с.* Үзендә тау һәм таш күп булган. *Суырлар ояларыннәрен сөрергә, ни дә булса чәчергә яраксыз уңдырышсыз, хәтта көтү йөртергә дә уңайсыз ташландык җирләргә, таулы-ташлы яссы тау битләренә казыйлар.* А.Хәсәнов

**ТАУЛЫ́-ЧОКЫРЛЫ** *с.* Таулары һәм чокыр-чакырлары күп булган. *– Менә син Бөгелмәдә торасың. Әйт, ул нинди урын? – Таулы-чокырлы бер урын.* Г.Әпсәләмов

**ТАУНХА́УС** *и. ингл.* Һәркайсы тулысынча мөстәкыйль берничә квартирлык, кайвакытта үз ишегалды яки бакчасы булган беркатлы яки азэтажлы торак йорт, торак комплексы. *Яңа коттедж, таунхаус хуҗалары кышларны ничек үткәрүен үзләре генә белә.* Кызыл таң

**ТАУСАГЫЗ** *и.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан тамырларыннан каучук алына торган күпьеллык үсемлек. *Каучук бирә торган үсемлекләр – таусагыз, кырымсагыз, күксагыз үсемлекләре ачылды.* Робинзон эзләреннән

**ТАУ-ТАРЛАВЫК** *җый. и.* Таулар һәм тарлавыклар. *Безнең илләр таутарлавык артында калды.* Р.Гаташ

**ТА́У-ТАУ** *с.* **1.** 1) Бергә, рәттән, янәшә торган таулар сыман, шуларга охшаган; бер-бер артлы тезелеп торган таулар рәвешендәге. *Зур болытлар күк йөзен каплап килә тау-тау булып.* М.Гафури. *Авыл ярлылары бер телем икмәккә иңрәгәндә дә, Садыйк ындырында тау-тау кибәннәр иде.* Г.Гали

2) *куч.* Бик күп булган, бик зур. *Ташладың тау-тау газаплар мин колыңның өстенә.* Һ.Такташ

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик күп, зур итеп. *Тел белән үзләре бик оста юмалыйлар, вәгъдәләрне тау-тау өләшәләр.* И.Гази. *Ә бездә ул пычкы чүбе тау-тау, кая итәргә белмибез.* З.Мурсиев

**ТАУ-ТАШ** *җый. и.* Таулы һәм ташлы урыннар; ташлы тау. *Хәрамиләрнең тау-таш арасында йөрергә күнеккән атлары дала атларын куып җитә алмады.* Р.Батулла. *Тау-ташлардан тора диңгез яры, Гөлләр үсә, ярып ташларны.* Р.Сәгъди

◊ **Тау-таш яру** Авыр эш эшләү. *Мин бер мескен татар идем, диеп җырламадым һәм дә җырламам: Тауташларны ярган бабаларым, зарланмаган алар дөньядан.* Г.Латыйп

**ТА́У ТӘКӘСЕ** *и. к.* **тау кәҗәсе**. *Тау тәкәсе тик торса, ач кала.* Мәкаль. *Әле Тибет түбәсенә качып, тау тәкәсе булып кыйланмакчымыни?* В.Имамов

**ТА́У ТИШЕГЕ** *и.* Мәгарә, гар, тау куышы. *Алар ишелергә торган кыя төбеннән, тарлавыклардан, судан яртылаш кына чыгып торган ташларга сикерә-сикерә үтеп, коточкыч бер көч белән коелып торган шарлама янындагы тау тишегенә килеп керделәр.* Г.Әпсәләмов. *Тавыш, тау тишегендәге төсле яңгырап, кыя ташларга бәрелде.* Р.Вәлиев

**ТА́У ТОКЫМЫ** *и. к.* **токым** (*6 мәгъ.*). *Таһир институтта өйрәнгән тау токымнары исемнәрен хәтеренә төшереп бара башлады...* Д.Булатова

**ТАУ-ЧАГЫЛ** *җый. и.* Урманлы, чытырманлы таулар һәм чокырлар. *Асылгәрәй әлеге киң басуларны, ерактагы соры кара урманнарны һәм таучагылларны, бер-бер артлы энә күзеннән үткәргән шикелле, яңадан җентекләп күзәтергә тотына.* М.Шабай

**ТАУ-ЧАГЫЛЛЫ** *с.* Урманлы, чытырманлы таулары һәм чокырлары булган. *Тау-чагыллы яклар*

**ТАУЧЫ** *и.* Тау токымнарын, җир асты байлыкларын, файдалы казылмаларны эзләү, тикшерү һәм файдалану, казып чыгару эшендәге эшче яки белгеч. *Таучы кәйлә белән туң җир чаба, маңгаеннан аның тир тама.* Д.Фәтхи. *Исәнмесез, дуслар, таучылар!* А.Хәлим

**ТАУЧЫЛЫК** *и.* 1) Тау токымнарын, җир асты байлыкларын, файдалы казылмаларны эзләү, тикшерү, табу эше. *Таучылык белгече*

2) *сир. к.* **альпинизм**. *Таучылык белән мавыгу*

**ТАУШАК** *с. диал.* Таушалган, тапталган. *Таушак үләнле сукмак буйлата беркадәр барганнан соң, Фәтхи --- елга кырыена барып чыкты.* Ш.Камал

**ТАУШАЛДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **таушалу**. *Акны күп таушалдырсаң, карага әйләнер.* Мәкаль. *Мине кемнәр теткәләде, Сизрәтеп бетерде? Кыршылдырып, таушалдырып, Көлке хәлгә китерде.* И.Гыйләҗев

2) *з-сыз.* Таушалырга туры килү. *Таушалдырган инде аны да*

**Таушалдыра төшү** Тагын да таушалдыру; бераз таушалдыру

**Таушалдырып бетерү** Бик нык таушалдыру. *Син дә тик ятмыйсың бит, әнә минем китапларны таушалдырып бетергәнсең.* Р.Мөхәммәдиев. *Гелән-гелән карап, дукәмитләрне таушалдырып бетермәгәек.* Л.Лерон

**Таушалдырып ташлау** Тиз арда таушалдыру. *Җәйгә керүгә, бер-бер артлы килгән салкын яңгырлар бәндәләрне бөтенләй үк таушалдырып ташлады.* Ф.Яхин

**ТАУШАЛУ** *ф.* 1) Тузу, сүсәрү, сизри башлау. *Таушалган портфель күтәргән Корнишин җыелган эшчеләр өстеннән бер күз йөртеп чыкты ---.* А.Алиш. *Илһам аны үз гомерендә бер генә мәртәбә таушалган, пычранган киемнән күрде.* Ф.Садриев

2) Ялтыравыгын югалту, ышкылып юкару (кәгазь тур.). *Әкрәм карый, ашыга-кабалана, бишмәтенең эчке кесәсенә тыгылды да, дүрткә бөкләп төрелгән кызыл яулык эчендәге кәгазьләр арасыннан иң таушалган берсен – имзалар урынына билге-тамгалар белән чуарланып беткән әлеге прошениене алып, морзага сузды.* М.Галәү. *Аннары шактый таушалган белешмә китапны актарды, үзалдына нидер мыгырдады.* А.Тимергалин

3) Бөгәрләнү, йомарлану. *Күлмәк таушалган, үтүкләмичә киярлек түгел.* Г.Әпсәләмов

4) Хәлсезләнүдән яисә дулкынланудан, куркынып һ.б.ш. сәбәпләрдән селкенү, калтырау. *Кисәк Котдус аягүрә басты, Нәзек иренен кысты, таушалды. Ул яварга килгән болыт кебек Йөз күрсәтеп сүзгә башлады.* Н.Баян

5) Машина, механизм һ.б.ш.ларның аерым өлешләре ашалып, ватылучан булып китү. --- *ярыйсы гына таушалган иске машина һәм өскә киелгән гади күлмәк-чалбар кунакның бүлекчәдә яңа гына эшли башлаган тәҗрибәсез хезмәткәр булуы турында тәфсилләп сөйләп бирделәр.* Ф.Бәллүр. *Нефть һәм газ сәнәгате тармагында җир астындагы торбалар беренче чиратта нәкъ бөкләнгән урында таушала.* Кызыл таң

6) Озак торганга, күптәннән кулланылганга искерү, тузу (йорт-җир тур.). *Өй бу яктан шактый искергән, таушалган булып күренә иде.* Ә.Еники. *Бу җимерелергә торган өйгә, таушалган ихатага карап әйтәсеңмени син аны?* Р.Кәрами

7) *күч.* Нindидер сәбәпләр аркасында көчсезләнү, эштән чыгу. *Дошман утына һаман каршылык күрсәтеп чигенүдән көчләр таушалу*

8) *күч.* Тулыканлылыгын, көчен югалту, хәлсезләнү; картаю, зәгыйфьләнү, бетәшү (кеше тур.). *Мотаһир аны көчкә таныды: түгәрәк кара сакалы ап-ак булган, үзе нык таушалган.* Р.Кәрами. *Кеше йөзе – гаҗәеп бер табигать табышмагы: бернинди җыерчык юк, бер генә ак чәч бөртеге күренми, ә менә бахырның бик нык таушалган, йончыган булуы ярылып ята.* З.Мурсиев

9) *күч.* Төсе киткән, чырае качкан, җыерчыкланган, суырылган, арыган булу (кеше йөзе тур.). *Йөзе йокыдан таушалган, күзләре рәтләп ачылып та җитмәгән, башындагы яулыгын да тискәре ягы белән япкан.* Г.Әпсәләмов

10) *күч.* Бетү; тынычсызлану, какшау. *Нервы таушала торгандыр инде.* З.Мурсиев

11) *күч.* Еш кулланылып образлылыгын, тәэсир көчен югалту (әдәби әсәр, алым, стиль, сәнгать чаралары тур.). *Кичер инде... Ни таушалган сүзләр!.. Тик мин түгел, аны теге көчләр Суырып ала эчтән җаным белән...* Э.Гадел. *Чамасыз еш куллана башласаң, сүз таушала, тоныклана, хәтта әкренләп үзенең асыл мәгънәсен югалта башлый, диләр.* М.Юныс

**Таушала бару** Торган саен ныграк таушалу. *«Кызыл йорт» дип исем алган фәхешханәләрнең күңел кайтаргыч күренешләре, анда килеп эләккәннәрнең мораль һәм физик яктан таушала барулары драмада шушы һәм башка образлар аркылы ачык гәүдәләндерелә.* Фәнни Татарстан

**Таушала башлау** Таушалырга тотыну. *Ул хатны Маһинур, кабат-кабат укып, үзе белән йөртте, таушала башлагач, иренең мендәре астына яшерде.* Р.Хәбибуллина. *Өстендә язгы юка куртка, аягында таушала башлаган көзге кроссовкалар.* Безнең гәҗит

**Таушала төшү** Берникадәр таушалу. *Кулында – бераз таушала төшкән калын папка.* А.Хәсәнов. *Анда аягына олтанлы киез итек, өстенә шактый таушала төшкән каеры тун, башына колакчынлы бүрек кигән өлкән яшьләрдәге бер агай басып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Таушалып бару** Торган саен ныграк таушалу. *Елдан-ел җиргә сеңеп, тузып, таушалып барган Бибинур карчык өендә генә мәет чыккандай тынлык, ул йортка беркем керми, чыкмый, хат ташучы да аяк басмый.* Т.Галиуллин

**Таушалып бетү** Тәмам, бик нык таушалу. *Бригадирлар да таушалып беткән куен дәфтәрләренә тотындылар.* А.Гыйләҗев. *Кыршылып, таушалып беткән чемодан эченнән мәтрүшкә-бөтнек исе, авыл исе аңкып килеп чыкты!* Г.Гыйльманов

**Таушалып килү** Соңгы арада таушала башлау. *Машинаң да таушалып килә, бәлки, монысын сатып, шәбрәген алырбыз, әйеме?* Ф.Яруллин

**Таушалып китү** Кыска арада сизелерлек таушалу. *Соңгы вакытта көннәр буе бала белән, бераз таушалып та киттең...* Г.Галиева

**Таушалып тору** Әле, хәзерге вакытта таушалу; әледән-әле таушалу. *Уф... Әллә нигә арып, таушалып торам.* А.Гыйләҗев

**ТАУШАРЫЛУ** *ф. диал. к.* **таушалу** (*1, 2 мәгъ.*). *[Пелагея Николаевна] бераз таушарылган күлмәк итәкләрен сыпыргалады.* Б.Камалов

**ТАУ ЭШЧЕСЕ** *и.* Таучылык тармагы эшчесе. *Зәки, революция башланганда, Харьковта булганга, андагы тау*

*эшчеләре батальонына куңелле гаскәри булып языла.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ТАФТА** *и. фр.* **1.** Тыгыз ефәк яисә мамык тукыма. *Туган көнгә күлмәк алдык Кызыл сары тафтадан. Бигрәк матур, анаң алган, Бәясенә бакмаган.* В.Ильясов. *[Кызның] Гәүдәсен тыгыз кара челтәр белән капладылар, алтын җепләр белән күпертеп чигелгән алтын тафтага төрделәр, муенына роза чәчәкләредәй сары ефәктән эрләнгән шарф урадылар.* К.Кәримов

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Тафта, органза, ефәк һәм атлас пәрдәләрне башта, салкын суда чылатып, тузаннан арындырырга кирәк.* Кызыл Таң

**ТАХИЛ** *и. гар. диал.* Яңа әйбер алу яисә башка берәр шатлык уңаеннан исерткеч эчү йоласы, гадәте. *Нужәли инде без ахырдан, әнә фәртмагка [продмагка] кереп, кандала исле тахил шәрабеннән авыз итмибез?* М.Мәһдиев

**ТАХИЛГӘ** *рәв.* Шатлык уңае белән, сөенечтән (исерткеч эчү тур.). *Тахилгә генә тавык та эчкән, ди.* Әйтем

**ТАХИЛИТ** *и. гр.* Обсидианга охшаш яшел, көрән, кара төсләрдәге минерал

**ТАХИЛЛӘҮ** *ф. диал.* Тахилгә эчү; сыйлап эчерү. *Тахилләдә бәхилләдә.* Әйтем

**Тахилләп кую** Аз гына тахилләү

**Тахилләп җибәрү** Бераз тахилләү. *Син, туган, тахилләп җибәргәнсең бугай, --- казна эшендәге кешегә исереп йөрү, ай-һай, килешеп бетмәс.* С.Рафиков

**ТАХИН** *и. гар. кулин.* Төелгән көнҗет орлыгы пастасы. *Тахин хәлвәсе. Тахин соусы*

**ТАХТА** *и. фар.* Артсыз киң һәм тәбәнәк диван. *Тахтага йомшак тире җәелгән иде, Таңчулпан шунда утырды, император аның янына кунды.* М.Хәбибуллин. *Бүлмәнең икенчесендә җиһаз азрак: түр почмакта җыйнак кына бер тахта, кухня өстәле һәм пыяла ишекле бәләкәй шкаф.* З.Хөснияр

**ТАЧ** I *кис.* **1.** 1) Нәкъ, бөтенләй, төптөгәл, тап (охшау, таман булу, туры килү тур.). *Ә ул төсе белән тач Хафиз абый кебек…* И.Юзеев. *Яңакларының чыгып торуы тач себер татарларыныкы кебек бит инде.* З.Зәйнуллин

2) Тап, нәкъ, кыл (кемнең-нәрсәнең дә булса төгәл бер урында урнашуы яки вакытка туры килүе тур.). *Тач шул вакытка туры килә, чукынмыш.* Ф.Яруллин. *--- дөрес әйткәнсең, алдамагансың. Тач шушы урында басып торалар иде.* Т.Миңнуллин

3) Тоташ, гел, бары тик. *Нижневартовск, Урай, Лангепас, Мегион калаларының халкы тач татар гына диярлек.* А.Хәсәнов. *Иртәнге чәйгә кунакка дәшәләр, биш тавык, ун үрдәк суялар, көндезге ашауга бүлтерек тәкә чалалар, ә кичке бәлешкә тач май сарыкны багышлыйлар…* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Тулысынча, бөтенләй. *Шулай да, җир йөзендә бер-берсенә тач охшаган бәндәләр булмаган шикелле, һәр гаиләнең үз ящәү рәвеше, башкалар күзенә кылчык булып кереп тормаган «милли колорит» була.* Т.Галиуллин. *И-и, бирсә бирә, кавыштырыйм дисә, кавыштыра Ходай холык-фигыльләре тач бертөсле булган бәндәләрен!* Ф.Баттал

**3.** *с. мәгъ.* Төгәл, туры килә торган, бик дөрес. *Бердән, ул тач, үткен бәя бирә, икенчедән, аның төрттерүе, чәнчеп алуы усал, явыз түгел.* Т.Галиуллин

◊ **Тач иттерү** 1) Төп-төгәл, бик дөрес һәм бик вакытлы, нәкъ кирәгенчә, тиешенчә эшләү, әйтү һ.б.ш. *Халкыбызда «тач иттереп әйтеп бирә» дигән сүз бар. Шуны мин Эльмира иҗатына карата да әйтер идем ---.* Б.Рәхимова; 2) Уйлап-нитеп тормыйча, тәвәккәлләп, бик тиз эш итү. *Зөбәй тач иттереп, Ачу белән куя икеле.* Совет әдәбияты. **Тач килү** 1) Тулысынча туры килү, төп-төгәл ярашлы булу. *– Тимучин баһадирга мондый ләкабь үтә тач киләдер, бик кулай, бик хуп, – дип, әүвәл Муенлык би мөһер суккан иде ---.* В.Имамов. *Бу картлачның фаразлары Безнең илгә тач килә. Кыек киткән юлыбызга Бигрәкләр дә мач килә.* И.Гыйләҗев; 2) Нык охшау. *Син дә, минем әби кебек, ап-ак чәчле икән. Бу яктан тач килгәнсез.* М.Хуҗин. **Тач китү** Нәкъ тиешенчә, кирәгенчә булу, әйбәт бару, дөрес килеп чыгу. *[Ләүкә башына] тас күтәреп таз киткән, Егылып төшкән: тач киткән!* Такмаза. **Тач өстенә (эзенә) басу** Бик дөрес, хаклы рәвештә, туры китереп әйтү һ.б.ш. *Ә ничек оста куша халык кушаматны! Тач өстенә генә баса да куя.* Г.Якупова. *Тач өстенә бастың, хәерчелек көчле: миңа бүген бер кульяулык алырлык та акча юк, күлмәк түгел.* К.Кара. **Тач үзе** 1) Нәкъ шундый, бик охшаган. *Тайфунның тач үзе икәнсең, бәрәкалла!* Ф.Баттал. *Ике малае бар аның. Тач үзе инде, шулкадәр охшаганнар.* З.Зәйнуллин; 2) Әйтелгән фикер белән тулысынча килешүне, «бик дөрес, шулай, әйе шул» мәгънәсен белдерә. *Быел? Әйе, шул, тач үзе!* Л.Лерон. **Тач төшү** *к.* **тач килү**. **Тач яту** *к.* **тач килү**. *Соң, җир алмасы ат итенә килешеп, тач ятып тора.* Т.Галиуллин

**ТАЧ** II *иярт.* 1) Нинди дә булса юеш өслеккә яки җиргә сугу, бәрү, китереп басу һ.б.ш.дан чыккан тавышны белдерә. *[Саввич], таш идәнгә ялана-якларының бөтен табаны белән тач-тач басып, эре-эре адымнар белән --- чыгып китте.* Ә.Фәйзи

2) Каты итеп, ачу белән төкерү рәвешен белдерә. *– Башыңны катырма, – диде Нурулла, дөнья күргән кешегә охшарга тырышып һәм тач итеп юл читенә төкерде.* Р.Мөхәммәдиев. *Әй торам чиратта, ач кешенең ачуы яман, ди, --- түзәр хәл калмагач, почмактагы пәрәмәч сатучыдан бер-ике пәрәмәч алып тамак ялгармын дип барган идем – чират, сатучының колагы да күренми, урап алганнар тегене, ачудан тач иттереп бер төкердем дә яңадан чиратыма кайттым ---.* Р.Батулла

**ТАЧ-** *ингл.* Мәгълүмат технологияләренә караган кушма терминнарда «кагылуга сизгер» мәгънәсен белдерә торган беренче компонент. *Иске Татар бистәсенең тулы бер тарихы белән махсус интерактив тач-панельләр, экраннар аша танышу күпләрдә кызыксыну уята.* Шәһри Казан

**ТАЧА́НКА** *и. иск. рус* 1) Дүрт тәгәрмәчле, пар атка җигелә торган сиртмәле җиңел арба. *Талибулла абый тачанка белән ат чабышында катнаша.* Бөгелмә авазы

2) Россиядә 1918–1920 еллардагы Гражданнар сугышы чорында пулемёт

урнаштырылган шундый арба. *Пар атка җигелгән җиңел тачанка өермә кебек алга ыргылды.* М.Хәсәнов. *Гражданнар сугышында Нестор Махно, тачанка уйлап табып, дала сугышлары тактикасын камилләштерә алган ---.* Р.Хәкимов

**ТА́ЧКА** *и. рус* 1) Гадәттә йөк ташу өчен файдаланыла торган бер тәгәрмәчле кул арбасы. *--- май ахырларында дүрт авылның халкы Пауал тегермәнен буарга җыела иде. Көрәк, сәнәк, ат, носилка (бездә: лачинкә), тачка, балта.* М.Мәһдиев. *Тачка белән үлән алып кайткач, атасы аның башын шулай дип сыйпый.* Ә.Гаффар

2) Шул арбага сыйган, күчерелгән йөк күләме. *Егерме бишәр тачка тәгәрәткән чаклар була.* Ш.Камал

3) *сөйл.* Җиңел автомобиль. *Тачкаларга аракы белән закуска төйибез дә әйдә пошёл!* Аманулла

**ТАЧКА́** *с. сөйл.* Түбән сыйфатлы оннан пешерелгән яки чиле-пешле, сыланучан, үзле (ипи тур.). *Ипиең тачка булса, бер көн ашарсың, хатының тачка булса нишләрсең?* Мәкаль

**ТАЧКАЛАНУ** *ф.* 1) Тачка килеп чыгу. *Тачкаланган ипи*

2) Тыгызлану, утыру; киезләнеп керешү, укмашу, оешу. *--- бик вак себергән туфрак өстенә, ихтимал, кувәтле яңгыр яуса, җир тәмам тыгызланып вә тачкаланып утырыр, җир һаман эшкә килмәс, бары хезмәт әрәм китәр ---.* К.Насыйри. *Кайчандыр мендәр эчендә тачкаланып яткан, хәзер инде иреккә чыккан йон кисәкләренең салкын идәнгә төшәселәре килми иде булса кирәк.* А.Шамов

**Тачкалана бару** Торган саен ныграк тачкалану

**Тачкалана төшү** Бераз тачкалану; тагын да тачкалану

**Тачкаланып бетү** Тәмам, бик нык тачкалану

**ТА́ЧКАЛАП** *рәв.* 1) Тачка белән; тачкаларга бүлеп, тачка-тачка итеп. *Тачкалап ташу*

2) Чама белән фәлән сандагы тачка күләмендә. *Утыз-кырык тачкалап балык чанга салынгач, Шәрәфи агай лабаздан чыкты.* Ш.Камал

**ТАЧКЫЛУ** *ф. сир.* Су, май кебек нәрсәләр кушып болгату, изү. *Җамали абзый --- кармакларына киндер мае белән тачкылган кызыл икмәк эләктереп, яр буена утырткан казыкларына кармак сапларын тезде.* Ә.Исхак

**ТАЧСКРИН** *и. ингл. информ.* Кул белән кагылуга сизгер экраннан гыйбарәт мәгълүмат кертү һәм чыгару җайланмасы; сенсор экран

**ТА́Ч-ТАЧ** *иярт.* 1) Юеш җирлеккә басып йөрүдән, суккалаудан чыккан авазларны белдерә

2) Авызны чәпелдәткәндә, үпкәндә чыккан авазларны белдерә. *Гаязетдин улын күтәреп алды һәм аны тач-тач үбәргә тотынды.* Р.Гаязетдин. *Авызыбызны тач-тач китереп, бүтән малайларны да кызыктырып ашау безгә ниндидер куаныч китерә иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТА́Ч-ТОЧ** *иярт. к.* **тач-тач**. *Тач-точ басып бара, гомердә кыланмаганны кылана.* Р.Камал. *Малай тач-точ кәнфит суыра башлады, Микрәб исә, чемоданын култык астына кыстырып, иплән кенә трамвай тукталышына юнәлде.* З.Мәхмүди

**ТАЧЫЛДАТУ** *ф.* 1) Тач-тач иткән тавыш чыгарып басу, атлау, сугу, бәрү, тач-тач китерү

2) *күч.* Турыдан ярып әйтү, кырыс, кискен рәвештә, йөзгә бәреп әйтү. *– Картлач, – диде Әхәт, Идриснең иңенә кулын салып. – Син шушы минутта үзеңнең кемлегеңне беләсеңме? – Беләм, – дип тачылдатты Идрис.* Казан утлары

**Тачылдатып алу** Кыска гына вакыт тачылдату

**Тачылдатып кую** Кинәт, бер мәртәбә тачылдату

**ТАЧЫЛДА́У** *ф.* 1) Тач-тач иткән тавыш чыгарып атлау

2) *күч.* Әрсез, ямьсез итеп сөйләү, сөйләшү. *«Апа, апа» дип, сүз саен тачылдама, яме, бала!* Н.Гыйматдинова

**Тачылдап алу** Берара тачылдау

**Тачылдап тору** Әле, хәзерге вакытта тачылдау; даими яки әледән-әле тачылдау. *[Мәрфуга:] Тик, әллә нидәй итеп, алдан тачылдап торуына ачуым килде.* Җ.Фәйзи

**ТАШ** *и.* **1.** 1) Һәртөрле каты минерал, тау токымы, шуның бер кисәге. *Йомшак, җылы келәмгә дип сузылган кулым салкын ташка килеп тиде.* Р.Мөхәммәдиев. *Таш бата, ә алма батмый суда!* М.Кәбиров

2) Шундый минералның бер төре, токымы. *Златоустка мәрмәр ташына заказ бирде, шуны китертеп, язулар яздыртып йөри.* М.Мәһдиев. *Көзгене алар обсидиан ташын ялтыраганчы ышкып шомарту юлы белән ясаганнар.* А.Тимергалин

3) Шундый минералдан кителгән яки кисеп ясалган, төзү материалы буларак файдаланылган кисәк; гомумән кирпеч. *Һәр ташына җан иңдереп төзелгән бу затлы храм архитекторның мәгънәле яшәвен, илһамлы иҗатын мәңгеләштергән һәйкәл түгелмени?* М.Галиев. *Шулай ук кечкенә генә бу авылда бүрек тегүчеләр, итек басучылар, тун тегүчеләр, шәл бәйләүчеләр, таш кисүчеләр, --- терлекчеләр, балык үрчетү осталары, яшелчәчеләр, тагы әллә кемнәр яши.* Т.Нәҗмиев // Юлларга түшәү өчен файдаланылган чуерташ, йомрыташ һ.б.ш. каты токым кисәкләре. *Таш түшәлмәгән урамнар адәм йөри алмаслык булып пычракка әйләнәләр.* Г.Ибраһимов. *Римның бер мәйданында урам ташына ак сызык сызганнар, шуннан атлап керүгә, син инде Ватикан территориясендә.* М.Мәһдиев

4) Шундый минералларның аерым максатларда файдаланыла торган кисәге; берәр эш коралының яки җиһазының детале. *Бакир чүмеч белән мич ташына су бөрки.* Н.Гыйматдинова. *Кызны күреп, Хәлим сискәнеп китте, әмма артык игътибар бирмәде, өске тегермән ташына беркетелгән имән саптан тотып, әйләндерде дә әйләндерде.* Г.Гыйльманов

5) Шундый минералларның кыйммәтле, декоратив, ювелирлык һ.б.ш. максатларда файдаланыла торган сирәк төре; шуның бер кисәге. *Әгәр дә хак булса, ахак ташына охшашлы зур бриллиант куелган бер беләзеге генә дә кеше гомеренә җитәрлек акча бәясе тора, ди.* М.Хәсәнов

6) Әлеге минералларның ювелир әйберләрдә бизәк буларак кулланыл-

ган, махсус эшкәртелгән кисәге; каш. *[Егет:] Оһо! Ташы ничек ялтырый [балдакның]! [Ир:] Таш түгел, гади пыяла ул. Кылый Кирам дигән бик оста ювелир эшләде моны.* Аманулла. *Әнә алтынланган көмештән ясалган мәрҗән беләзекнең ахак, фирүзә ташлары ничек ялт-йолт килеп тора.* М.Әмирханов

7) *сөйл.* Руда, мәгъдән. *Берәүләр, аны шахтада таш баскан, дип сөйли, икенчеләре, Миршәех исән дә, Бибисарасыннан куркып, Акъярга кайтмый, имеш, дип көлә иде.* Г.Әпсәләмов. *Акланга алар күн капчыкларга тутырып бакыр ташы алып килгәннәр иде.* Н.Фәттах

8) Вафат булган кешенең истәлеген мәңгеләштерү өчен, кабере өстенә куелган билге; ташбилге. *Анда, Казанда, Арча кыры зиратында, түбәнге якта, мәгърур тирәк төбендә, «Шагыйрә Дулатова Кәримә» дигән язулы таш куелган кабер әле дә бардыр ---.* Ф.Яхин. *Әниләрен, ап-ак кәфенгә төреп, бик зурлап җирләделәр. Ап-ак мәрмәр таш куйдылар. Чардуган да алып кайтканнар иде дә, анысын куйдырмадым.* Д.Салихов

9) Берәр нәрсәнең истәлеге, билгесе итеп куелган стела, һәйкәл. *Шуннан соң атабыз --- иң калку җиргә биек таш утыртып куйган, ташны уеп, киләчәк буыннар өчен үзенең изге сүзләрен, юсык-юрык кагыйдәләрен язып калдырган.* Н.Фәттах. *Ул үзе исән, ләкин һәйкәл-истәлек ташына, үлгәннәр белән беррәттән, аның исемен дә язып куйганнар.* Р.Низами

10) *тар.* Ярты чакрым чамасы арага тигез булган үлчәү берәмлеге. *Бер таш җир китү*

11) Организм эшчәнлегендә булган берәр тайпылыш, авыру аркасында эчке әгъзаларда барлыкка килгән каты төер. *Ихтимал, Мишә буена балыкка килгән өч дусның, өч авылдашның да инде кайсында таш, кайсында холецистит, кайсында Боткин авыруы – әллә ниткән чуртымнар бардыр.* М.Мәһдиев. *Ә-ә, холецистит инде ул синең. Үт куыгына таш утырганнан була ул.* Р.Батулла

12) Сызыклы уенында кулланыла торган әсбап; шакмак

13) Шахмат, шулай ук шашка уенында гадәттә аклардан һәм каралардан торган уен фигураларының һәрберсе. *Уенчыларның мат куярга ташлары җитмәү*

14) *күч.* Күңелне нык борчып торган гаеп, бурыч, чарасызлык һ.б.ш. кебек авыр хис. *Авыр таш бар кебек күңелдә.* Ф.Хуҗин

15) *күч.* Кыенлык, михнәт; киртә, тоткарлык. *Болар – физик яктан авыру хәлдә дә рух ныклыгын югалтмыйча, тормышның якасына ябышып, үзләрен бастырган язмыш ташы астыннан чыгарга тырышучылар ---.* Ф.Ярруллин. *Шагыйрь чын мәгънәсендә хаклы: Кемнәрнең юк Тормыш ташына бәрелеп җанын канатканы?* И.Вәлиулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Таштан (*1 мәгъ.*) гыйбарәт, шуннан торган, шуннан ясалган. *Район үзәгендәге таш һәйкәлне күз алдына китерде ул.* Ф.Хуҗин. *Тамаша белән кызыксынучы карт-коры һәм бала-чагалар мәйдан тирәсендәге өй һәм таш коймалар яныннан карап тора.* Н.Яһудин

2) Ташы (*1 мәгъ.*) күп булган, ташлы. *Биргән җире таш булды, биргән орлыгы пыш булды – шытмады.* Н.Исәнбәт

3) *иск.* Балчыктан ясалган; керамик. *Ә Исмәгыйль алтын иясенә үз куллары белән бер таш чүлмәк кымыз тоттырды.* М.Әмирханов. *Ниһаять, мәхәлләне туйдырырга житәрлек таш табак белән табынга пылау килде.* Ә.Шәмин

4) Үзлегеннән бик тыгыз, каты булган яки махсус тыгызлап, пресслап эшләнгән (тоз һ.б.ш. матдәләр тур.). *Диңгез саегу белән тозлы күлләр ясалып, гипс, ангидрид, таш тоз һәм башка утырмалар хасил булганнар.* А.Фәткуллин. *Таш ягулык*

5) *иск.* Түшәмәсе, капламасы булган; йомрыташ, чуерташ, ташкирпеч һ.б.ш. түшәлгән. *Ярый әле, тарантаслары рессорлы, югыйсә рессорсыз тарантас таш юлда бик яман сикертә ул.* Ә.Еники // *сөйл.* Асфальтлы. *Бер-ике көннән аларның җимерек машинасын таш юл буендагы куаклар артында күрәләр.* А.Тимергалин

6) *күч.* Эре бөртекле, зур. *Ука аралаш таш энҗеләр белән чигелгән эрелевәклы калфаклар, кәттәҗиләр күтәргән хатыннар мәш килә.* К.Тинчурин

7) *күч.* Бернинди тойгыга бирелми торган, битараф, салкын. *Өченчедән, монысы тагын да әһәмиятлерәк, егет кеше шигырь язмасын, таш күңелле инженер да булмасын!* Ф.Яхин

8) *күч.* Бернинди тойгыны да белдерми, чагылдырмый торган, битараф, салкын, җансыз (чырай, йөз һ.б.ш. тур.). *Әлтафига борылдылар, аның таш йөзен, җансыз карашын тойдылар һәм нәкъ баягы урында бөгелеп төшеп көлә башладылар.* М.Мәһдиев

9) *күч.* Куркыныч, усал, кырыс (чырай, йөз һ.б.ш. тур.). *Хәлил, кесәсеннән алып, кечкенә кара күзлек киде, һәм мин куркып киттем: шул мизгелдә үк ул мәет төсле таш чырайлы кешегә әверелде дә куйды.* Ф.Садриев

10) *күч.* Кызгану, шәфкать белми торган, рәхимсез, аяусыз. *Аның таш күңелен йомшартырга кирәк.* М.Маликова

◊ **Таш астыннан чыккан** 1) Бик үткен, чая, булдыклы, зур авырлыкларны, кыенлыкларны җиңеп чыгарлык. *Үзе солдат булган кеше, сөйләгәндә, авызыннан ут чыга, әрхиреендә дә булган, губернаторын да күргән – таш астыннан чыккан кеше ---.* Г.Исхакый; 2) Теләсә нинди кыек эшкә өйрәнгән, бик остарган, шомарган. *Алар белән бәхәсләшүдән файда юк: барыбер җиңеп булмаячак. Чөнки алар өчәү. Шуның өстенә, таш астыннан чыккандай, бик үткен малайлар.* В.Нуруллин. **Таш ату** 1) Кемне дә булса гаепләү, яманлау, аңа зыян китерергә тырышу. *Миңа таш аткан кеше дә – шигырь язып та эш майтара алмаган бер көнчел бәндәдер!* Р.Батулла. *Үзебез кебек кыерсытылганнардан, кимсетелгәннәрдән гаеп табып, сүгеп, киләчәгебезгә таш атмаска, бар халыкларны бергә тартучы дошман тегерменәнә су коймаска иде.* Н.Гариф; 2) Димләп карау. *--- кызлар ауларга чыкканнар! Нинди түбәнлек! Башта Лида исемле кызга «таш атып» караган, тегесе «алдыңнан артың матур» дигәч, икенче кызга барып сырышкан...* А.Гыйләҗев. **Таш белән ату** Берәр кешегә, гадәттә аның яхшылыгына каршы яманлык эшләү. **Таш**

**булып басу** *к.* **таш булып яту**. *Аста калу хурлыгы, Ивашка белән чәкәләшеп күпме вакытның әрәм узу үкенече, талчыбыкларның һаман да сатылмау кайгысы – һәммәсе дә бергә укмашып, Әхмәдулланың күңелен авыр таш булып басты.* Л.Зөлкарнәй. **Таш булып бату** Яшь килен кияү гаиләсендә әйбәт яшәп китү, кияүгә уңышлы чыгу, кияүгә киткәннән соң кайтмау. *Төшкән нигезенә тәү көннән үк таш булып батты Мәрьям.* Д.Булатова. **Таш булып кату** 1) Курку, кисәк, берәр авыр хәбәр һ.б.ш.дан хәрәкәтсез калу, катып калу. *Нурулла бер сүз дә әйтә алмады, башы таш булып катты, колак төбендә һаман теге ручканың чертләгәне ишетелеп торды.* Ф.Садриев. *Тагын су бөрки, Куян һушына килә, ләкин, Бүрене күреп, таш булып катып кала.* Р.Фатихов; 2) Кайгы, рәнҗү һ.б.ш.лардан күңел кату; суыну, хиссезләнү. *Ул бит таш кебек каткан, аннан сиңа нинди наз да нинди сан булыр икән?* Т.Гыйззәт. *Шуңа да аларга нәфрәт һәм җирәнү тойгысы йөрәгендә гомергә эремәс таш булып катты.* З.Мурсиев. **Таш булып утыру** 1) *к.* **таш булып яту**. *Җә Ходай, болай булгач, бакыйга да бәгыренә таш булып утырган шушы хәвефле хәбәр озатачак бит инде.* М.Әмирханов. *Соңгы көннәрдә күңеленә таш булып утырган кайгы-хәсрәт ташып чыккан иде инде.* Г.Исхакова; 2) Берәр сәбәптән ризык тамактан үтмәү, ашарлык булмау. *Авызына капкан ризыгы тамагына таш булып утырды Нәгыймьнең.* К.Кара. **Таш булып яту** Күңелгә бик авыр тәэсир итү, күңелне яралау, нык борчу. *Аның күңелен ниндидер аңлаешсыз бушлык, канәгатьсезлек хисе биләп алды, ниндидер сызлаткыч нәрсә йөрәгенә авыр таш булып ятты.* М.Галәү. *Әле монда да күңеленә авыр таш булып ятардай хәлләр күп булыр.* Г.Гыйльманов. **Таш йоткандай** Бер сүз дә әйтмичә, гомумән эндәшмичә; һич селкенмәстән. *Сүз өзелде, Рушания, урыныннан кузгалмыйча, таш йоткандай утыра бирде.* З.Кадыйрова. **Таш йоткан кебек** *к.* **таш йоткандай**. **Ташка әйләнү** Хиссезләнү, тупаслану. *Мәхәббәт хисе күңелләрне гомер буе яктыртып, җылытып тормаса, күңел ташка, дөм караңгыга әйләнер иде.* Г.Хөсәенов. **Ташка баскан кебек** Һичшиксез, шөбһәсез, икеләнүсез. *Анлары инде ни булачагы ташка баскан кебек ап-ачык.* М.Хәсәнов. **Ташка басу** 1) Китап бастыру, нәшер итү. *Ул китапларны ничәмә-ничә тапкыр сукалап чыгуымны әйтә алмыйм, ләкин көз җитеп, беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергәндә, мин инде ташка басканны шактый ук сөрә белә идем.* Туганнар; 2) Кистереп, ап-ачык итеп әйтү; ышандырып әйтү. *Борынгылар сүзе, ташка басылган сүзләр. Шәт, бабаларыбыз белми-нитми генә әйтмәгәннәрдер.* Г.Гомәр. **Ташка басылу** Нәшер ителү. *Күз алдына китерегез: ташка басылган беренче шигырь!* Н.Нәҗми. – *Шигырьләреңне басарбыз дигән идек. Мәнә ташка басылгач ничегрәк булган, укып кара, – дип, газетаны Фәниярга бирде.* Ф.Яруллин. **Ташка бәргән борчак кебек** Әйтелгән сүзләрнең тиешенчә кабул ителмәве, тыңлаучыга тәэсир итмәве турында. *Яхшы теләктән чыгып сөйләшүнең бу бәндә өчен ташка бәргән борчак кебек икәнлеген төшенгәч, Халисә --- китте.* С.Рафиков. **Ташка борчак бәрү** Мәгънәсез, файдасыз эш эшләү; буш сүз сөйләү. **Ташка борчак сибү** *к.* **ташка борчак бәрү**. *Наданга сүз әйтү – ташка борчак сибү.* Мәкаль. *Сез, гомумән, ташка борчак сибеп йөрүче фантазёр икән.* А.Гыйләҗев. **Ташка тамга салган** Берәр эш-хәлнең һичшиксез булачагы, башкарылачагы турында. *Дүрт малайны хәрби хезмәткә озату, кем әйтмешли, ташка тамга салган шикелле: берсе кайтып алты ай узуга, икенчесе китә.* Т.Нәҗмиев. **Ташка үлчим** 1) Берәр нәрсәнең тиешле сыйфатта, кирәкле дәрәҗәдә булмавы турында. --- *гәҗитләребезнең теле ташка үлчим. Кайда телебезнең аһәңе, моңы, табигый агышы? Журналист аларның итәгенә ябышып түгел, ә аларны үзе җитәкләп барырга тиешле.* Р.Фәйзуллин. --- *көннең көн буе коеп яуган яңгыр болай да ташка үлчим генә булган авыл юлларын тәмам эштән чыгара.* Р.Мостафин; 2) Берәр авыру, гариплек һ.б.ш. турында сүз чыкканда, «үзебезгә шулай була күрмәсен» мәгънәсендә. *Алар турысын әйтмәсәләр дә, теге ташка үлчим чир икәнен төшендем.* Г.Әпсәләмов. *Чияле хатын-кызларының телләренә тилчә чыккан, диләр иде, дөрес икән. Ташка үлчим, тфү!* Р.Батулла. **Таш кебек** 1) Бик каты, бик тыгыз; 2) Бик авыр. *Кинәт Мәмлинең уң як яңагына, күз турысынарак, таш кебек авыр йодрык килеп тиде.* Н.Фәттах. *Аягында көчкә басып тора. Гәүдәсе таш кебек авырайды.* Р.Низамиев; 3) Һавада эленеп тора ала торган каурый, яфрак, мамык кебек җиңел нәрсәләрдән аермалы буларак, авыр нәрсәләрнең туп-туры, зур тизлек белән төшүе турында. *Әле кыргый, ачы тавышлар чыгарып кычкыра-кычкыра, күкнең иң биек җиренә атылып менеп китә, әле, кара таш кебек сызгырып, түбәнгә мәтәлә [козгын].* Г.Әпсәләмов. --- *Әмәтхан утырган кечкенә самолёт җиргә таба зур тизлек белән таш кебек төшә башлый.* З.Зәйнуллин; 4) Үтә сәламәт, бик таза, нык; типсә тимер өзәрлек. *Гайнан физик яктан таза, таш кебек нык булып үсә.* Р.Мостафин. – *Сәламәтлекләрегез ничек соң, беркөе генә ятасызмы? – диде Ирек, әле әнисенә, әле әтисенә карап. Хәйри кетелдәп көлеп куйды: – Таш кебек, улым. Мәнә авыл советын җитәкләргә кодаладылар. Сәламәтлеге начар кеше шундый эшкә алынамыни?* Ф.Садриев; 5) *к.* **таш йоткандай**. *Шуңа күрә яшь хатын хафа кичерми, таш кебек хәрәкәтсез, җансыз иде.* Р.Батулла. **Таш кебек кату** *к.* **таш булып кату**. *Җәмил селкенми дә, чөнки йөрәге таш кебек каткан, эрергә уйламый.* Н.Әхмәдиев. *Таш кебек, җансыз сын сыман катты да калды.* М.Вәлиев. *Таш кебек катып торма, хәзер үк бармагыңнан балдагыңны салып өстәлгә куй.* С.Сабиров. **Таш кискәнмени** *к.* **таш кистеңме әллә?** *Таш кискәнмени, арып, Урынга ауды барып.* Р.Корбан. **Таш кистеңме әллә?** Бик арыган кыяфәт чыгарган кешегә карата киная белән әйтелә. *Нәрсә, таш кистеңме әллә? Яшь кенә башың белән кояш чыкканчы йоклап ятасың.* С.Кудаш. **Таш өстендә**

**таш калдырмау** Берәр нәрсәне тармар итү, нигезенә кадәр җимереп бетерү, юк итү, юкка чыгару. *Волостька китәм, юлда очраган авыллардан кешеләр җыям да комитетларына һөҗүм итәм, таш өстендә таш калдырмый ватам, җимерәм, үзләрен асам, кисәм!* Т.Гыйззәт. *Иван Калита Тверь, Кашин, Турҗик (Торжок) калаларын таш өстендә таш калдырмый һәлак итте.* Безнең мирас. **Таш өстендә таш калмау** Берәр нәрсә нигезенә кадәр җимерелеп бетү, юк ителү, юкка чыгарылу. *Идел буендагы Болгар, Биләр, Җүкәтау, Сарай, Үкәк, Гөлестан шикелле кайчандыр гөрләп торган зур шәһәрләрдән таш өстендә таш калмаганлыгын, хәтта Казан булып Казанның да элекке биналары тәмам җимерелеп, алар урынына бөтенләй яңалары килеп утырганлыгын алыйк.* М.Госманов. *Бөеклекме шулай ауган – биек түбәләр, арып, Җиргә төшкән – ята, ишеген, михрабын тузан сарып... Таш өстендә таш калмаган, җир елый гүя: авыр... Хәлсез гөмбәзләр... җан ачып – кем, каян аваз салыр?!* Р.Гаташ. **Таш өстендә таш куймау** *к.* **таш өстендә таш калдырмау**. **Таш салдыру** Киләчәгеңне белү өчен, багучыга барып фал ачтыру. *Юл чыгам дип таш салдырдым, Динебез кушмаса да.* В.Ильясов. **Таш салу** 1) Сайлау вакытында тавыш бирү. *Бу юлы яшерен тавыш белән болар сайлады баш: Әксәре [күпчелеге] салган боларның бер яңа тартайга таш.* М.Гафури; 2) Таш ярдәмендә күрәзәлек итү, багу, фал ачу; ногыт салу. *Бабам сугышка киткәндә, Кем соң таш салган икән? Ташлар яхшы күрсәтсә дә, Ник үлеп калган икән?* В.Ильясов. *Әнинең туганы да таш сала торган булган.* Хезмәт даны. **Таштай кату** *к.* **таш булып кату**. **Таштан юкә каезлау** *к.* **таштан юкә сую**. **Таштан юкә суйдыру** Мөмкин булмаган нәрсә эшләргә мәҗбүр итү, чынлыкка ашыру мөмкин булмаган таләп кую. *Чирек азагы җиттеме, таштан юкә суйдыра башлый: йөз процент өлгереш таләп итә генә бит.* Казан утлары. **Таштан юкә сую** Мөмкин булмастай эшне башкару, булдыру. *Тик вакыйгалар болай куерып киткәч, таштан юкә суюыбыз да гаҗәп булмастыр.* Т.Әйди. *Күпме тирләә, таштан юкә суеп булмый, Сыер менеп аргымакны узып булмый. Табигатьтән бирелмәсә рухи сәләт, Үзең теләп, бөек даһи булып булмый.* Р.Ханнанов. **Таштан яралган** 1) Бик нык, таза, сәламәт, аруга, авыруга бирешми торган бик түзем кеше турында. *Немецлар да таштан яралмагандыр. Бүген инде, сөзгәк сыер сыман, тагы да ярсый-ярсый сөзешергә килмәсләр.* С.Поварисов; 2) Куркусыз, кыю, чая кеше турында. *Сезнең шикелле таштан яралган егет куркырга тиеш түгел.* Г.Әпсәләмов; 3) *к.* **ташбәгырь**. *[Һуберт:] Елап кара, бәлки, кызганырбыз. [Гыйният:] Булмас, сезнең йөрәк таштан яралган.* Т.Гыйззәт. **Ташы кызу** Берәр эш-хәл вакытында түземсезләнү, чама хисен оныту, артык кызыгып, мавыгып, кызып, ярсып китү. *Хәмитләр экспедициягә ярдәм итәргә булдылар. Ташлары кызды малайларның.* А.Тимергалин. *Ташы кызган егет җавап көтеп тормады, әсир хатын артыннан ташланды һәм ике сикереп, бер атлап куып җитте дә кочаклап алды.* Т.Әйди. **Ташы суыну** Көн үзәгеннән төшү, кискенлеге, актуальлеге бетү; сүрелү, кимү. *Ул чорларның ташы суынса да, әрнүүкенечләре һаман шул килеш.* М.Кәбиров. **Таш яру** 1) Бик көчле, гайрәтле, тәэсирле булу. *Тсс!.. Тавышың таш яра.* Г.Мөхәммәтшин. *Колак төбендә яңгыраган һушыңны алырлык, таш ярырлык тавыштан икебез дә сискәнеп киттек.* В.Нуриев; 2) Мөмкин булмастай эшне башкарып чыгу, булдыру. *Таш ярырлык тәвәккәл, үҗәт егет ич ул, бармак янауга тугарылып бетә торган мәхлук түгел.* Т.Әйди. *Тырыш, улым, тырышкан таш яра, хәзер белемле кешеләр заманы.* Р.Шәрипова. **Таш ярылса да** Бернинди каршылыкка, комачауга карамастан. *Мидхәт ата күркәдәй кабарына һәм, үз дигәнен таш ярылса да эшләргә дип, учларына төкергәләп куя иде.* Ф.Хөсни. **Таш яуса да** *к.* **таш ярылса да**. *Таш яуса да, миңа кайтырга кирәк.* Н.Әхмәдиев. *Яңгыр түгел, таш яуса да, постыңны ташларга ярамый.* Ф.Хуҗин

**ТА́ШАГАЧ** *и. бот.* Киндерчәләр семьялыгыннан ташлы коры туфракларда үсә торган, каты яфраклы, үтә нык үзагачлы яфрак коючан агач; *русчасы:* **каркас**

**ТА́ШАКТАРЫР ШӨЛДИ** *и. зоол.* Шөлди кошлар семьялыгыннан, Скандинавия диңгез буйларында оялый торган уртача зурлыктагы күчмә кош; ташлык шөлдие; *русчасы:* **камнешарка**. *Гади ташактарыр шөлдинең иң якын кардәше – кара ташактарыр шөлди*

**ТАШАЯК** *и.* **1.** 1) Балчыктан ясалган, керамик савыт-саба

2) Балчык табак, тирән керамик савыт. *XIII–XIV йөз Болгар мәдәнияте җимешләре – алка, йөзек, кувшин, тәлинкә, лампа, ташаяклар күп.* Т.Әйди. *Ташаяктагы җылымса бәрәңгене бик тәмләп бөгеп салгач, мин дә конюшни өенә китәм.* Р.Төхфәтуллин

3) Фарфор, чынаяк савыт-саба. *Иртә язда да бакчада матур ташаяк кыйпылчыклары эзләргә яраткан кызларын бакчага чыгармады, җирне борчытмады.* Н.Кәримова

4) *диал.* Фарфор савыт-саба ватыгы, чынаяк кыйпылчыгы. *Кышын түгелгән чүп өемнәрен актарабыз. Шаккатарлык матур бизәкле ташаяклар килеп чыга алардан.* Ш.Маннур. *Бакчада ташаяк (чынаяк-тәлинкә кыйпылчыклары) җыеп маташканда килеп керә ул.* К.Җәмит

**2.** *с. мәгъ.* 1) Балчыктан ясалган, керамик. *Даңгөл, җиңелчә генә кагылып, кунак егете алдына читенә каңәфер чәчәкләре төшерелгән ташаяк тәлинкә куйды.* А.Хәсәнов

2) Фарфордан, чынаяк материалдан ясалган. *Өстәлдә ялтыратылган җиз самавыр, самавыр камфуркысында ташаяк чәйнек фырт кына утыра.* Р.Батулла

◊ **Ташаяк мунчаласы** Үтә катлаулы, авыр, четерекле, мәшәкатьле эш турында (элек Казанның Ташаяк бистәсе иске арканны сүтеп, шуның сүсен яңадан эшкәртү урыны булган). **Ташаяк мунчаласын үзең сүт** Гадәттә үз гаебе белән катлаулы, четерекле хәлгә төшкән кешегә ярдәм итүдән баш тартуны белдерә

**ТАШАЯКЛЫ** *и.* Пыяла, керамика, фарфор һ.б.ш.ның кыйпылчыклары белән уйнала торган балалар уены; тәтиле. *Малайлар ташаяклы уйный, мин дә ялантәпи генә шулар катына йөгерәм.* Ш.Маннур

**ТАШБАКА** *и.* 1) *зоол.* Ташбакалар отрядына кергән, гәүдәсе сөяк һәм мөгез (яки калын тире) катламыннан торган көбә – панцирь белән капланган, хәвеф чыкканда, башын һәм аякларын шул көбә эченә яшерә торган хайван. *Ә мәктәп бакчасы! Ә җанлы почмак! Сап-сары тутыйкошлар, ташбака, тритоннар...* А.Тимергалин. *Аның учында кул сәгатеннән чак кына зуррак ташбака баласы иде.* Р.Кәрами

2) *сөйл.* Шахтада файдалы казылманы кисү, җир астыннан чыгару һ.б.ш. машинасы; тау комбайны. *Ташбакалар, сүз куешкан кебек, беравыздан, бөтен лава буйлап шатырдатып, күмер кисә башладылар.* М.Сөндекле

3) *хәрби* Борынгы гаскәрләрдә диварларны, манараларны һ.б.ш.ларны җимерү өчен кулланылган, чылбырларга тагылган бүрәнәдән гыйбарәт бәргече һәм саклану өчен түбәсе булган җайланма. *«Таран» сүзе үзенең тәңгәлен тапмаган. Урта гасырларда гарәпләр кальга диварларын җимертү өчен файдаланган бер җайланма «ташбака» дип аталган. Бәлки, шулдыр?* А.Тимергалин

4) Борынгы Рим гаскәрендә җәяүле сугышчыларның бик тыгыз басып, калканнарны стройның һәр ягыннан тоташ дивар һәм түшәм хасил итәрлек тотып басу рәвеше; һөҗүм яки саклану өчен кулланылган шундый тактик алым. *Багучы йөзбаш аңа әйтте: каладагы легионерлар әле булса борынгы каһарман Искәндәрнең ташбака ысулын куллаңалар икән. --- Бу мәлдә зур кала мәйданында ташбакалар ясап, легионерлар гуннарны көтәләр иде инде.* М.Хәбибуллин

5) *күч.* Бик акрын хәрәкәт итә торган транспорт чарасы һ.б.ш.лар. *Без бит сезнең ташбаканы ә дигәнче чакрым ярым калдырып китәбез!* А.Тимергалин

6) *күч.* Бик акрын кыймылдаучан кеше, мыштырдык

7) *күч. иск.* Хезмәт ярышында артта калучы

◊ **Ташбака адымы** Берәр эшгамәлне бик акрын башкару, акрын хәрәкәтләнү турында. *Рәшит аганың докладын тыңлаганнан соң, кайсыдыр: «Нигә газификация эше сузыла, ташбака адымы белән бара?» – дигән сорау бирде.* Т.Нәҗмиев. *Ташбака адымы белән генә булса да алга баруың хәерле.* Ф.Дәүләтбаев. **Ташбака барышы** *к.* **ташбака адымы**. *Безнең барыш тагы ташбака барышына әйләнде.* Ф.Әмирхан

**ТАШБАКАЛАР** *и. күпл. зоол.* Сөйрәлүчеләр классының бер отрядын тәшкил иткән, гәүдәсе көбә – панцирь белән капланган, тропик һәм уртача климатик зонада җирдә, тозлы һәм төче суларда тереклек итүче хайваннар

**ТАШБАСМА** *и.* Ташка уеп эшләнгән рәсемне, язуны турыдан-туры кәгазьгә төшерү ысулы; литография. *Аның [Г.Баязитовның] ташбасмада чыккан «Татар теленең сарыф вә нәхүе» дигән китабы да бар.* М.Мәһдиев. *Ул [Хөсәен Фәезханов] татар телен өйрәнү өлкәсендә дә күп эшли, ташбасма (литография) ысулы белән «Краткая учебная грамматика татарского языка» (1862) дигән хезмәтен бастыра, шулай ук төрки телләр сүзлеген һәм хрестоматиясен төзи.* А.Гайнетдинов

**ТАШБАСМАХАНӘ** *и.* Литография ысулы белән китап һ.б.ш. бастырып чыгара торган типография. *Аның [Әбдеш Ваһаповның] «Русско-татарская азбука» исемле дәреслеге беренче кат 1852 елда, аннан 1856, 1860, 1862 елларда Казанда басыла. «Басманың эре һәм вак хәрефләре» дигән плакатәлифбасы 1863 елда ташбасмаханәдә басылып чыга.* И.Рәми

**ТАШБАШ** I *и.* **1.** 1) Бик шук, чая, усал, тәвәккәл малай, егет. *Теге ташбаш тагын берәр ярамаган эш майтаргандыр әле?!* Ф.Имамов

2) Үткен, акыллы, башы тиз эшли торган зирәк бала. *Еш кына республика күләмендәге олимпиадаларда катнашкан, җиңеп кайткан бу ташбашлар өчен берни түгел ул.* А.Хәсәнов. *--- маршалның исемнәренә хәтле каян белгән диген ташбаш Саматны!* Т.Нурмөхәмммәтов

3) Гомумән ир бала, малай. *Без, малайлар, әтинең өч ташбашы, кулга эләккән һәр кәгазь битенә ат башы ясыйбыз.* А.Хәсәнов. *Малай дигәннән, синең улың да, минем ташбаш кебек, мәктәпне тәмамлый түгелме әле?* Х.Мөдәррисова

4) Хулиган, бандит. *Ә теге оятсыз адәм төрмәдән генә чыккан, бөтен Сәнгыйләйне дер селкетеп тоткан ташбаш булган икән.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чая, шук, усал, тыңлаусыз. *Нибары егерме ел элек без – ядрә шикелле ташбаш малайлар – күзге коры төннәрдә, олы егетләргә охшатып, тын урамнарда гармун белән җырлап йөри идек.* М.Мәһдиев. *Тоткыннарның күпчелеге – җиде-сигез, унөч-унбиш яшьләрдәге кыз-кыркын һәм ташбаш малай-шалай.* В.Имамов

2) Үзсүзле, тискәре холыклы. *Их, киребеткән, тискәре ташбаш малай син!* Н.Әхмәдиев

3) Аңлаусыз, аңгыра. *Аның кирәк икәнен ташбаш бюрократларга исбат итәрлек дәлилләр булсын, димен.* З.Мурсиев

**ТАШБАШ** II *и.* Карплар семьялыгыннан төче сулыкларда тереклек итә торган, башы гәүдәсеннән чагыштырмача зуррак булган вак балык; комкорсак; *русчасы*: **пескарь**. *Ләкин ни хикмәттер, балык үрчемәде, кимегәннән-кими барып, күлләр-елгалар-чишмәләрдәге затлы балыклар тәмам бетте, этләй белән ташбаш кына калды!* Р.Батулла. *Яр читендә утыра карт, Калкавычка инәлеп. Бер ташбаш капкан иде дә, Кире җибәрде никтер.* Г.Морат

**ТАШБӘГЫРЬ** *и.* 1) Үтә битараф, салкын күңелле кеше. *Беләм, беләм ташбәгырьләр Заманасы икәнен. Күрәсем килә таш ярып Матур чәчәк үскәнен.* Г.Ибушев

2) Кызгану, шәфкать белми торган, кансыз, рәхимсез, аяусыз кеше

**ТАШБИЛГЕ** *и.* 1) Билге өчен яки кемнеңдер яки нәрсәнеңдер истәлегенә утыртылган таш. *Археологик казу эшләре вакытында тикшерелгән борынгы зират урынына, эшләребезне тәмамлагач, ташбилге куеп китәргә уйладык.* Казан утлары

2) Кабер ташы. *1981 елның көзендә шул зиратларны өйрәнгәндә, без Гарифҗан оста эшләгән йөзгә якын ташбилге барлыгын ачыклаган идек.* Гасырлар авазы. *Дусай авылы эчендәге аерым каберлектә XVII гасырга караган ике ташбилге янәшә тора.* Безнең мирас

**ТАШБОРЧАК** *и.* Үтә саран, кысмыр кеше. *Ирем ахырда: «Ул ташборчакка ялынаммы соң, кечкенәдән үк карун булды», – дип, кул селтәде.* Р.Кәрами

**ТА́ШВАТКЫЧ** *и.* **1.** Каты токымнарны ваклый торган машина. *Монда әле дә көне-төне Гөрли экскаваторлар, коперлар, Ташваткычлар, бетон болгаткычлар – Иң көчле, Иң яңа моторлар.* С.Урайский

**2.** *с. мәгъ.* Таш вату өчен билгеләнгән. *Моның өчен, таштагы ярыклардан файдаланып, экскаватор белән зур кисәкләр аерып алалар һәм аларны ташваткыч корал белән кирәкле үлчәмле итеп ваталар.* Төзү материаллары. *Ә майлагыч presslар, шарлы тегермәннәр, эретү мичләре, ташваткыч агрегатлар һәм механик иләкләрне каян алабыз?* Казан утлары

**ТАШЙӨРӘК** *и. к.* **ташбәгырь**. *Бу хәтле дә ташйөрәк булырсың икән!* Ә.Еники. --- *көенмәгән, борчылмаган, бигрәкләр дә ташйөрәк, бигрәкләр дә каты бәгырь булыр икән.* Г.Ахунов

**ТАШКАБАК** *и. бот.* Кабакчалар семьялыгыннан яшел, сары, кара яки ак төстәге озынча җимешле, гади кабакның куакчыл төре һәм шуның чиләтә дә, пешереп тә ашала торган җимеше; кабакча. *Ташкабак организмда җиңел үзләштерелгәнлектән, ашказаны, эчәкләр, бавыр (гепатит, холецистит, үт куыгында таш барлыкка килү) ялкынсынганда билгеләнә торган барлык диеталар составына керә.* Казан утлары

**ТАШКАЛАК** *с.* 1) Тиз таша торган, ташучан

2) Тар күңелле; кызып китүчән, ачуы тиз кабарып ярсучан. *Тар казан – ташкалак.* Мәкаль

**ТАШКАПЧЫК** *и.* 1) Төрмә. *Надзиратель этеп-төртеп карцерга тыкты да тимер ишекне шалтыратып ябып бикләде. --- Озынлыгы биш, киңлеге өч метр чамасындагы ташкапчык – тәрәзәсез дүрт цемент стена.* И.Салахов. *Бу бала кайсыгызныкы була? Ишетсен колагы: берәр әйберем югалса, хәзер милиция чакыртам! Утыртып куялар читлеккә, ташкапчыктан чыкмаслык итәләр!* Ф.Яхин

2) Сугышта тулы, котылгысыз камалыш, тозак, божра. *Бөтен өерегезне ташкапчыкка эшереп керттек, берәмберәм Газраилгә биреп торачакбыз.* М.Әмирханов

3) Тар, кысан, тиешле шартлары булмаган яшәү яки эш урыны (гадәттә шәһәр җирендәге йортлар тур.). *Мәктәпнең ишегалдында гына клуб чаклы зур агач йорт. Мондагы шикелле ташкапчык түгел инде.* Казан утлары

**ТА́ШКИСКЕЧ** *и. махс.* **1.** 1) Таш кисү өчен махсус эш коралы. *Мәргәннәр, мин азат түгел, кулымда кылыч урынына һәрчак ташкискеч булды.* М.Хәбибуллин

2) Ташны кирпеч, блок һ.б.ш. формадагы кисәкләргә кисә торган махсус механизм, машина, җайланма

**2.** *с. мәгъ.* Таш кисә торган, таш кисү өчен билгеләнгән, шуңа кулланылган. *Ташкискеч өтерге – «Аждаһа теше» кебек коралларга ул гел мохтаҗ булды.* Р.Батулла. *Инженер ташкискеч машиналар белән дә комбайннныкы кебек дүрт кырлы ташлар алып булганын Клеймёновка исбат иткән иде.* Ш.Бикчурин

**ТАШКУРАН** *и. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан Ерак Көнчыгыш тауларында тереклек итә торган, тыгыз гәүдәле, кыска аяклы, кәҗәгә охшаш сирәк хайван; куран; *русчасы:* **горал**

**ТАШКУРЧАК** *и.* 1) *иск.* Балчык, гипс яки б.ш. материалдан ясалган буяулы курчак. *Ташкурчакка охшаган авыр нәрсәнең өстенә киндер кисәге капланган. Бу Карман сака әнисенең бер батман авырлыгындагы алтын сыны иде.* Н.Фәттах

2) *күч.* Карар күзгә матур гына, ләкин хиссез, җансыз, артык салкын кеше (гадәттә хатын-кыз тур.). *Чәчләрен лакка катырган, агач сынлы, ясалма озын керфек-тырнаклы ташкурчаклар аңа кат-кат җан өшеткеч итеп елмайдылар.* Ф.Җамалетдинова

◊ **Ташкурчак кебек** 1) Бик чибәр. *Ташкурчак кебек матур бу кыз белән Мөхәммәт күптән таныш.* З.Хөснияр; 2) Зиһенсез, акылсыз; 3) Тирә-якка игътибар итмичә, бернинди реакция бирмичә, дәшмичә; аңышмыйча. *Чөнки ни чәйнәгәнен, ни йотканын белмичә, ташкурчак кебек утырды.* Р.Габделхакова; 4) Бизәнгән-ясанган, матур киенгән

**ТАШКҮЛЧИМ** *с. к.* **ташка үлчим**. *Ләкин студентларның әзерлеге ташкүлчим, нибары ике тапкыр җыелдык: саф дигәннең исе дә юк, сыер көтүе кебек, беребез алда, икенчебез артта.* И.Салахов. *Ә шактый белемле ул үзе. Архитектор булган. Ә тормышы – ташкүлчим...* Р.Кутуй

**ТАШКҮМЕР** *и.* Ягулык буларак файдаланылган, соры күмер белән антрацит арасында торган, борынгы үсемлекләрнең органик калдыклары югары басым һәм температура нәтиҗәсендә күмерләнүдән барлыкка килгән янучан каты файдалы казылма. *Нефть әле аз чыга, ә ташкүмер шахталары кайда гына юк.* Н.Әхмәдиев. *Картада тимер, нефть, ташкүмер ятмалары һәм башка төр файдалы казылмалар аерым билгеләр белән күрсәтелгән.* Р.Мостафин

**ТАШКҮҢЕЛ** *и. к.* **ташбәгырь**. *Ташкүңелләр аңламас риккать дигән сүз кадрене.* Г.Тукай. *Үз куышың булыр. Бу ташкүңелләрдән котылырсың!* М.Маликова

**ТАШКЫН** *и.* **1.** 1) Көчле явымтөшем, кар эрү һ.б.ш. сәбәпләрдән сулыктагы су югарылыгы күтәрелеп, ярларыннан чыгу, гадәттәге агым юлын үзгәртү күренеше; су басу, ташу. *Унсигезе тулган язда армия сафларына чакыру көткән көннәрендә, әзмәвердәй егет булып өлгергән Рамил, ташкын суына төшеп, күз ачып йомганчы юк булды...* А.Хәйртдинова. *Губернатор В.Якушев язгы ташкынга каршы чараларга багышланган селектор киңәшмәсендә катнашты.* Яңарыш

2) Бик көчле агым; көчле агымлы елга, канал һ.б.ш.лар. --- *[дөяләрнең] берсе сикереп аккан ташкынга ташланган һәм теге як ярга йөзеп чыккан.* М.Мәһдиев. *Бу тау елгасы башка урыннарда көчле ташкын, ап-ак күбек булып бөтерелеп-бөтерелеп ала да,*

*менә шушы үзәнлеккә килеп чыккач, чабыштан килгән юртак кебек, тынып, сабырланып кала, киң булып җәелеп ага.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Бер юнәлештә күпләп хәрәкәт иткән кешеләр, транспорт чаралары һ.б.ш.лар; көчле агым. *Хәзер халык ташкыны туздырылган умарта илен хәтерләтә иде.* А.Расих. *Төн урталары булганга, шәһәр урамнары машиналар ташкыныннан бушап калган.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Зур интенсивлык белән башкарылган эш-гамәл, фикер; берәр объектка юнәлдерелгән көчле процесс. *Икенче мәлдә, фикер ташкынын эзгә төшерергә бик зур тырышлык куеп, көчкә-көчкә эндәшә алды: – Хатны укып карарга буламы?* Х.Камалов. *Шул ук вакытта, әсәрләр үзләре дә заман таләпләренә җавап бирерлек, әйткәнемчә, мәгълүмат ташкынында үзенә җәлеп итәрлек булсын иде.* Р.Фәйзуллин

5) *күч.* Хис-кичерешләрнең гадәттән тыш тулылыгы, көчлелеге һәм интенсивлыгы. *Күңеленә, җир астыннан чишмә бәреп чыккандай ургылып, хисләр ташкыны килеп тула.* А.Хәсәнов

6) *күч.* Берәр төрле зур, әһәмиятле күренешнең, вакыйганың көчле барышы, котылгысызлыгы. *Бөтен Рәсәйне инкыйлаб ташкыны басып киткән бер заман иде бу.* Ә.Еники. *Милли азатлык хәрәкәте ташкынын хәзер берниндиди көч тә туктата алмаячак.* Р.Миңнуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тулы сулы, ярларыннан ташып чыккан; ярларына, улагына сыймаган; шаулап, гөрләп ага торган. *Анары керсәң чыга алмаслык заваллар, бер дә көтелмәгән җирдә мина кырлары, каты агымлы ташкын елгалар, берсе артына берсе яшеренеп торган биеклекләр, баткак сазлар китә.* Г.Әпсәләмов. *Аяк астында сайлап салынгандай чиста, шома вак ташлар кыштырдады, --- артта, беркемгә, бернәрсәгә колак салмыйча, мәңге хәрәкәттә яткан ташкын дәрья шаулап калды.* Н.Фәттах

2) *күч.* Кызу канлы, ярсу, ярсынучан. *Ташкын булсаң – басыл, шашкын булсаң – асыл.* Мәкаль

3) *күч.* Бик көчле, ташып торган, ярсулы (хис һ.б.ш. тур.). *Ул гүя бары йөрәгендәге ташкын тойгыларын йөрәк көче белән тота алмаганнан гына шулай җырлап җибәргән.* Һ.Такташ. *Кызның йөрәк сере бар, киленнең кыймас сүзе бар, толның бетмәс зары бар, егетнең ташкын дәрте бар ---.* Г.Хөсәенов

4) Ашкынучан, дәртле, хисчән (күңел, характер һ.б.ш. тур.). *Шаукымымы үткән давылымның, Давыл көтеп әллә тынуым. Тик сизәмен ташкын күңелемнең Күзгә сулар кебек тонуын.* Р.Бикбаев

**ТАШКЫНЛАНУ** *ф.* 1) Ташкын булып, ургылып, ярсып агу. *Арада Шивилгән үзәк урамыннан шарлап, ташкынланып агып төшкән сае-елгачыгы белән, күкрәп, бертоташтан үсеп киткән йөзем-җимеш бакчалары белән дан тота иде.* Ә.Мохтар. *Һәр яз саен сулар гына Ярдан чыга ташкынланып. Ә минем күңелем тыныч, Инде бүтән ашкынмамын.* Г.Әхтәмова

2) *күч.* Тынгысызлану, ярсыну, ашкыну. *Мәхәббәт шулай давылланып, ташкынланып килә дер дип уйламаган иде Мәрхабә.* Г.Әпсәләмов. *Йөрәгемдә җылы дулкын булып Ташкынланган чагы хисләрнең...* Р.Харис

**Ташкынлана бару** Торган саен ныграк ташкынлану

**Ташкынлана төшү** Тагын да ташкынлану

**Ташкынланып тору** Әле ташкын хәлдә булу; даими яки әледән-әле ташкынлану

**ТАШКЫНЛЫ** *с.* 1) Таша торган; ташкыны булган, ташкын булып агып, ургылып торган. *Ел буе гел ташкынлы яз гына була алмый икән шул.* Х.Хәйруллин. *Әнә шулай империя дәрәҗәсенә ирешкән каханат Самандар, Итил, Бәхтияр, Актүбә, Шайтан каласы кебек кала-кальгаларын югалта, ягъни бу калалар барысы да су астында калалар, я ташкынлы елгалар тарафыннан юылалар.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Ярсулы, дәртле, ашкынулы. *Татар халкы бу 20 ел эчендә дәртле һәм ташкынлы музыкалары, җырлары белән күңелләребездә горурлык уята торган талантлы композиторлар, җырчылар тудырды.* М.Җәлил. *Акыл менә шушы кайнап торган ташкынлы күңелдә, һәр кичерешнең чамасын билгеләп, гармония («фәлсәфи караш») сакларга тиеш.* Р.Сафин

3) Бик зур һәм тиз үзгәрешләр булган; тынгысыз, хәвефле, куркыныч. *Бу дәвернең ташкынлы елларында Гаяз Исхакыйның патшачылыкка каршы хәрәкәт иткән һәр группага катнашлыгы була.* Казан утлары

**ТАШКЫНЛЫК** *и.* 1) Көчле агымлы булу; ташкынлы булу күренеше. *Үзенең ташкынлыгы белән, ярларының гүзәллеге, суының арыклыгы белән Итил җир йөзендәге Фатих ибн Әхмәт белгән бер генә елгага да охшамаган иде.* Н.Фәттах. *Авыллар иркенлеген һәм язгы дәрьялар ташкынлыгын үзләре белән бергә алып килгән яшь җаннар.* М.Вәлиев

2) *күч.* Дәртлелек, ашкынучанлык, тынгысызлык. *Дәрдемәндтә фикерләр йомшак хисләр белән бизәкләндерелгән булса, Тукайда хисләр фикергә чыланган була. Сәгыйть Рәмидәге кеби анда шашкынлык та юк, табигый вә түземле бер ташкынлык бар.* Г.Сәгъди

3) *күч.* Ярсып китүчәнлек, кызу холыклылык. *Ташкынлыкның соңы – шашкынлык.* Мәкаль

**ТАШКЫНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тыныч, салмак агымлы, тулып ташып тормаган; ташкын булмаган

2) *күч.* Салкын, рухсыз, дәртсез. *Ташкынсыз күңел*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ташкын булмаган хәлдә; ташкын барлыкка китермичә. *Казанда бер генә яз да ташкынсыз үтми. Елга ташкынсыз ага*

2) *күч.* Тыныч кына, артык дулкынланмыйча, ярсусыз. *Шулвакыт аның башына, бик табигый агымнар белән, бер дә дулкынсыз, ташкынсыз гына, мең төрле уй килеп кичә.* Г.Ибраһимов

**ТАШКЫРАН** *и. бот.* Ташкыранчалар семьялыгыннан ташлы туфракларда, кыя ярыкларында үсә торган башлыча күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **камнеломка**

**ТАШКЫРА́НЧАЛАР** *и. күпл.* Башлыча төньяк ярымшарның уртача климатлы зонасында таралган 30 ыру һәм 600 гә якын төрне берләштергән күпьеллык һәм берьеллык үлән үсемлекләр семьялыгы. --- *арбутин гликозиды – ар-*

*чанчалардан (вересковые) саз чабыр куагында (багульник болотный), талкан утында (толокнянка) һәм рододендронда; --- ташкыранчалардан (камнеломковые) чагырда (бадан); оешмачәчәклеләрдән (сложноцветные) тиле тигәнәктә (дурнишник) бар.* Агулы үсемлекләр

**ТАШЛАМА** *и.* 1) Алдан билгеләнгән бәя, норма һ.б.ш.ны киметү, төшерү гамәле; бәянең киметелгән өлеше. *Ни өчен алар ике йөз сиксән меңдә туктаганнар? Чөнки сезнең дә ташлама ясавыгызны көтәләр.* Ә.Еники. *Бер сумлык ташлама илле тиенлек ришвәт булып кайта. Тегеләр дә канәгать, болар да.* И.Әмирхан

2) Кемгә яки нәрсәгә карата куелган гомуми таләпләрне, кагыйдәләрне йомшарту, норманы киметү, хаталарын өлешчә гафу итү һ.б.ш.дан гыйбарәт эш итү алымы, якын килү принцибы. *Киленнең һич кенә дә укытучы икәнлегенә ташлама ясамады: мәктәптә озак торасың, дип каһәрләде, кичләрен план төзергә утыргач, крәчин маен күп тотасың, дип йөргән бозды ---.* М.Мәһдиев. *Баштагы елларда халык аны, беренче чиратта, тән газапларын җиңүче көчле рухлы зат, егетләр егете дип үз итсә, соңгы елларда, бернинди ташлама ясамыйча, зур язучы-әдип итеп кабул итте.* Р.Фәйзуллин

**ТАШЛАМАЛЫ** *с.* Ташламасы булган; ташламага нигезләнгән. *Ял йортларына ташламалы яисә бушлай юллamaларны Казанда Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгыннан бүлеп бирәләр.* Л.Локманова

**ТАШЛАНДЫК** *с.* **1.** 1) Искерү, тузу, кирәге калмау һ.б.ш. сәбәпле куллланудан чыккан, ыргытылган, ташланган. *Ул аяк астындагы ләмнән ташландык бер дәү ләгән табып алды.* М.Мәһдиев. *Ташландык техника чыннан да очрый, ләкин вертолёт тапканыбыз юк иде әле.* И.Хуҗин

2) Кеше яшәми торган; кеше файдаланмый торган. *Ул ташландык йортка күчеп утыручы да булмады.* Р.Батулла. *Шул елда язучыларга кирпеч заводының ташландык карьерын бакча итәргә рөхсәт бирелгән иде.* Ф.Яруллин

3) Тәртипкә китерелмәгән, каралмаган, төзекләндерелмәгән. *Гөл кебек тотасы урында, торган йортын карамады, ташландык хәлгә җиткерде.* Р.Фәйзуллин. --- *спорт корылмалары төзибез, ә башкалабыз уртасындагы тарихи биналарга игътибар итмибез. Уникаль йортлар ташландык хәлдә кала бирә.* Р.Шакир

4) Ата-ана тарафыннан калдырылган, гаиләдән кире кагылган; ятим. *Ташландык балага бәхет әзерләп куйганнар ди сиңа, көтеп тор.* Г.Гыйльманов. --- *күпләр, беби-бокслар ташландык сабыйларның тагын да артуына китерәчәк, дип фаразлый.* Г.Насыйбуллина

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кирәксез дип табылган, ташланган нәрсә. *Кайчандыр сирәк субтропик агачлар гына үстерелгән булып, бүген ташландыклар күргәзмәсенә әйләнгән бакча сукмагыннан җитәкләшеп төшеп килүче ир белән хатынга тап булдым.* А.Хәлим

2) *күч.* Үз сыйныфы, катламы, даирәсе һ.б.ш.ларның тышында калган, кабул ителмәгән кеше; артык, кирәксез күрелгән, читкә этелгән кеше. *Син киткәч, без икебез бертигез булып калдык. Ул да ташландык, мин дә.* Э.Яһудин

3) Ата-анасы тәрбияләүдән баш тарткан, калдырып киткән бала. *Юлдан табып кая китергәннәр? Исеме дә шунда кушылган. Ташландыклар түгел, табылдыклар Булып үскән күпләр шушыннан.* К.Булатова

**ТАШЛАНДЫКЛЫК** *и.* Ташландык булу хәле. *Кая карама, әле башланып кына килгән төзелешләрдә очрый торган ташландыклык, актарылган, умырылган җир күзгә ташлана ---.* А.Хәлим

**ТАШЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ташлау**. *Эзли торгач, иске, ташланган коены таптылар.* М.Гафури. *Чүп-чар полиэтилен капчыкларга җыела һәм шул капчыгы белән чыгарып ташлана.* Т.Әйди

2) Югарыдан аска таба атылу, сикерү, ыргылып төшә башлау. *Яраткан егетләренә кияүгә чыга алмаган бәхетсез япон кызлары шул вулкан кратерына ташланып үләләр, ди.* В.Имамов

3) Берәр юнәлештә кискен хәрәкәт ясау, берәр нәрсәгә табан ыргылу. *Көтмәгәндә ул урыныннан торды, кулындагы камчысын кырт кына селтәп алды да ишеккә ташланды ---.* Н.Фәттах

4) Берәр утыргыч яки ятакка гәүдәнең бөтен авырлыгы белән килеп төшү, үзен шул урынга ату. *Ида тизрәк койкасына ташланды, одеялын башына каплады да, коты алынып, дердер калтыранып, аның [Сәгыйтьнең] бүлмәгә килеп кергәнен көтә башлады.* Н.Фәттах

5) Гәүдәне кисәк берәр якка авыштыру. *Министр артка ташланып шаркылдап көлеп җибәрде.* З.Мурсиев

6) Кемгә дә булса һөҗүм итү, ябырылып өскә килү. *Капкаларын гына ачкан идек, бер зур эт өстебезгә ташланды.* А.Алиш. *Асылгәрәй карт аны тыңлап тормады, атылып, Сарбай өстенә ташланды, алар икесе бергә яр астына тәгәрәп төштеләр.* Ф.Бәйрәмова

7) Кыюлык белән ут, су һ.б.ш. берәр куркыныч мохит эченә керү. *Әгәр дә, баягы кызны күрү мөмкин, дисәләр, әйе, әйе, бары тик тагын бер кабат күреп калу гына булса да мөмкин, дия алсалар, Нажар, йөзә белмәгән хәлдә, су тирәнлегенә, өметсез хәлдә дә бозлы шарлама астына ташланыр иде.* Ә.Баян

8) *күч.* Берәр шөгыльгә нык бирелү, мавыгып китү, онытылып, шуны гына эшли башлау; берәр мохиткә чуму, шуңа омтылу

9) *күч.* Уйлап тормыйча, тәвәккәл рәвештә, тулысынча бирелү (берәр хистойгы тур.). *Күрәм, әфәнделәр, сезнең берегезнең дә мәхәббәт дәрьясына ташланганы булмаган икән.* М.Әмирханов

**Ташлана бару** Регуляр төстә ташлану; әкренләп ташлану. *Яңадан-яңа җырлар чыгып, искеләре ташлана барган саен, бу мөнәсәбәтсезлек арта барган.* Гали Рәхим

**Ташлана башлау** Ташланырга тотыну. --- *көннең икенче яртысында, моннан ерак түгел аэродром бар икәнлеген белдереп, һавага күтәрелүче һәм, кире-сенчә, җиргә түбәнәюче самолётлар еш күзгә ташлана башлады.* Ф.Хуҗин

**Ташлана тору** Әледән-әле ташлану. *Кинәт... туры гына барган уңайдан машинабыз чалыклый башлады, әле уңга, әле сулга ташлана торгач, шома бозга*

*эләктеме – кырт борылып, урам кырыендагы мәһабәт йортка таба жуылдап очарга тотынды (Гәрәй тормоз урынына газга баскан булган икән).* М.Галиев

**Ташланып бетү** Тәмам, бөтенләйгә ташлану. --- *аның бара торган сукмагы ташланып беткән иске сукмак булса да, Дәүләт халкының Болгар шәһәренә килә торган юллары булуыннан Сатыш әфәндегә таныш иде.* Ф.Туйкин

**Ташланып карау** Ташлану алымын сынау; ташланырга тырышу. *24 ендә Канзафар һәм Салават отрядлары янә һөҗүмгә ташланып карыйлар, әмма туплар уты астында кире чигенәләр.* В.Имамов

**Ташланып тору** Әле ташлану; даими яки әледән-әле ташлану. *Аларның ниндидер бер эчке тоемлау, зәвык белән чын күңелдән үрелгәннәре әллә каян күзгә ташланып тора.* А.Мансуров

**ТАШЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ташлау**. *Киләчәктә игезәк балаларның берәрсе үзен дә тәхеттән бәреп төшерәнитә күрмәсен дип куркып, Амули патша Рем белән Ромулны Тибр елгасына ташлата.* Н.Фәттах. *Эчүне ташлата торган әфсенем бар минем, Әхмәт абый.* Ә.Моталлапов

2) Сөт бирүдән вакытлыча туктау; савылмый тору. *Бозаулар алдыннан сыер ташлата, сөт бирми башлый бит.* Ватаным Татарстан

**Ташлата бару** Акрынлап ташлату

**Ташлата башлау** Ташлатырга тотыну. *Татарстанлыларга чүпне икегә аерып ташлата башлыйлар.* Сабантуй. *Бәлки, кайбер сыерлар ташлата да башлагандыр, сөтнең кимүенә шул сәбәпледер.* Заман сулышы

**Ташлатып карау** Ташлатырга тырышу. *Шуннан соң аларның бу бидгать гамәлләрен ташлатып кара.* Безнең гәҗит

**Ташлатып тору** Билгеле вакытка, вакытлыча, әлегә ташлату. *Зобанилык Таһир – Зөһрәләрне Тора һаман суга ташлатып. Күңелләрдән көн дә куалыйбыз Хозырильяслыкны… таш атып.* З.Мансуров. *Соң, гади акыл белән уйлап карагыз: сыер елга бер-ике ай сөтне ташлатып тора, бер ай бозавы имә.* Казан утлары

**ТАШЛА́У** *ф.* **1**. 1) Нәрсәне дә булса көч белән берәр юнәлештә ыргыту, атып җибәрү. --- *күктә көнбатышка таба төркем-төркем очып үткән һәм, бомбаларын ташлаганнан соң, тәртип белән тезелешеп кайткан кызыл йолдызлы самолётларны да бөтен халык күрә бит.* А.Тимергалин. *Сихерчеләр тарак ташлаганнар: Юлларыңда баскан карурман...* Р.Әхмәтҗанов

2) Саксызлык, ачу һ.б.ш. сәбәп белән тиешсез җиргә яки тиешсез рәвештә кую, ату, ыргыту. *Аннан соң, Газизә абыстайның аяк тавышы ишетелгән шикелле булгач, Хәят портретны тәрәзә төбенә ташлады да бүленгән эшенә тотынган сыман итте.* Ф.Әмирхан. *Нигә дип трубканы ташладың син?* Н.Кәримова

3) Нәрсәгәдер төбәп, шул якка, шул юнәлештә берәр нәрсә белән ату, тондыру. *Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән.* Г.Тукай

4) Кирәге беткәнгә яки башка сәбәп яки максат белән аңлы рәвештә кулланмый башлау, куллanудан баш тарту. *[Мирвәли:] Юк инде, әти, безнең кулга корал эләккән икән, аны ташларга ярамый.* Т.Гыйззәт. *Улларының таягын ташлап титаклый-титаклый йөри башлаганын күрү ата-анага иң зур шатлыкларның берсе булды.* З.Зәйнуллин

5) Кирәге беткән, искергән, җимерелгән, бозылган һ.б.ш. нәрсәдән котылу, чыгарып ату. *Бар, бу шакшы төргәкне чүплеккә чыгарып ташла!* М.Әмирханов. *Чыннан да, егетнең тунын ташлап кына калдырасы калган.* З.Мурсиев

6) Берәр нәрсәне тоту, эләктерү, тоткарлау һ.б.ш. максат белән махсус җайланма, корал салу. *Тыныч кына аккан суга суалчан кидерелгән кармакны ташлыйсың да шул калкавычка карап торасың.* З.Бәшири. *Томанлы һавада хәрәкәт итәргә куркып булса кирәк, дүрт кораб та ачык диңгездә, якорьларын ташлап, өч тәүлек буена бер урында тордылар.* Ф.Хуҗин. *Ләкин ул янә бер ятьмә ташлады.* З.Мурсиев

7) Кешән, элмәк, богау кебек нәрсә кидерү, салу. *Баркаска керүгә, муеннарына элмәк ташлый-ташлый, әсирләрне бер арканга беркетә башладылар.* В.Имамов. *Бөтенесе дә Абилне чолгап алалар, Кавил элмәк ташлый, бәйли башлыйлар.* Г.Каюмов

8) Нәрсәне дә булса бер әйбернең өстенә, алдына яки аркылы итеп салу, элү. *Иртән торуга, җилкапка киләсенә бау ташлап, Җидесу елгасына алып барган үр сукмакка төшә.* Г.Гыйльманов. *Кәлүшиле итек-сүчинкә киеп, җилкәсенә аркан бәйләмен ташлап, Соры Гыймади акрын һәм авыр адымнары белән кузгалып китте.* Ф.Яхин

9) Газ, су кебек нәрсәләрнең күләм, басым һ.б.ш. артып торган күрсәткечен киметү өчен, аңа сыйдырыштан чыгу, агу мөмкинлеге бирү, юл ачу. *Гидротехник корылмалар – су һәм плотиналар, гидроэлектростанция, су ташлау, су төшерү һәм су чыгару корылмалары, туннельләр, каналлар ---.* Көмеш кыңгырау

10) Вакытыннан элек балалау, корсак салу, төшерү (терлек тур.). *Бозлавыкта бозау ташлар, җәйләүдә җилен башлар.* Әйтем // Кою, ату (үсемлекләр тур.). *Ак каеннар яфрак ташлады. Вак яңгырлар ява башлады.* Р.Миңнуллин

11) Билгеле юнәлештә кискен хәрәкәт ясау, изәү, селтәү, кизәнү. *Чуар халатыннан йомры тез башларын алга ташлый-ташлый, Мифтахның хәләл җефете керде.* Т.Галиуллин. *Шушы сүзләр белән кыз, башын горур чайкап, чәчләрен артка ташлады да атлап китеп тә барды.* З.Мурсиев

12) Билгеле бер торышка кую, бер якка тайпылдыру, авыштыру. *Башын артка ташлап, йомшак түшәгенә ятты да күзләрен йомды.* Г.Гыйльманов. *Аның янына утырган Бәдриҗамал, башын артка ташлап, авызын ачып йоклап китеп бара иде.* Н.Кәримова

13) Берәр авыр хәлгә кую, кыенлыкка дучар итү. *Инде, колхоз дип, актык баламны җиде ят кулына, эт оясына ташлар хәлем юк.* А.Алиш. *Шуннан соң патшалар алмашына башлады, алмашынган бере минем байлыгымны талап үзенә ала да мине зинданга ташлый ---.* Р.Батулла. *Кеше сүзенә колак куеп, үз җанымны җавапсыз сораулар газабына ташлап ни оттым инде, я?* Ф.Яхин

14) Нәрсәнеңдер кирәкмәгән, тиеш булмаган өлешен алмау, төшереп калдыру. *[Шаһит – тикшерүчегә:] Үзем белгәнне сөйлим. Каләм кулыңда бит: кирәген алырсың, кирәкмәгәнен ташларсың.* Г.Ибраһимов

15) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса калдырып китү. *Җәй җитү белән, алар, шәһәрдәге тынчу өйләрен ташлап, табигать кочагына, җәйләүгә чыкканнар...* А.Тимергалин. --- *халык кадәр халыкның җир-су ташлап кубып китүендә әллә никадәр тарихи фаҗигаләр ята...* Р.Фәйзуллин

16) *күч.* Берәр эштә, ярышта узып китү, артта калдыру. *Ул [кыз], чынлап та, чаңгыда бик оста йөри икән. Бераздан мине шактый ук ташлап та китте.* Ф.Хөсни. *Һи, сезгәме соң минем арттан җитәргә. Теләсәм, мин сезне ун чакрымга ташлап калдырам.* С.Шакир

17) *күч.* Игътибарсыз, ярдәмсез калдыру, ярдәм итмәү. *Бөтен авыл халкы аларны гаепләгәндә, алар кайгысына сөенгәндә, бер Камилләр гаиләсе генә аларны якын итә, ташламый иде.* Ф.Бәйрәмова. *Бу игелегең өчен Ходай ташламас үзеңне, аның колагына бөтен белгән догаларымны укып торырмын...* Г.Гыйльманов

18) *күч.* Берәүгә карата мәхәббәт тотудан туктау, аның белән гыйшык мөнәсәбәтләрен өзү. *Юк, көнләшмим. Чөнки Әкълимәнең Һабил кебек изге затны ташлап, сиңа каравына ышанмыймын.* М.Кәбиров

19) Нинди дә булса эш-шөгыльне кую, туктату, аннан аерылып тору. *Хәнифәдән башкалары барысы да, эшләрен ташлап, урам як тәрәзәләргә йөгерде.* Н.Яһүдин. *Болай да колакларын торгызып утырган хатыннар, фалның шулай башлануын ишетеп, кул эшләрен ташлап, күзләрен боларга текәделәр.* Н.Кәримова

20) Нинди дә булса даими шөгыльдән тыелу, ваз кичү, берәр (ешрак – начар) гадәтне бетерү. *Я бу азгынлыгын-бозыклыгын ташлап кешечә яши башлый, я инфекцияле шприцлардан әҗәлен таба: хәзер барысы да фәкать ирнең үзеннән тора иде.* М.Кәбиров. *Алар шулай яхшы гына яшәп ятарлар иде бит, әгәр дә хатыны сүзен тыңлап, Талбай урлашуын ташлаган булса.* З.Мурсиев

21) Кемне яки нәрсәне дә булса ашыгыч рәвештә, күпләп билгеле эшкә, өлкәгә, тармакка юнәлтү, күчерү. *Гөлкәйнең киявен, фин кампаниясендә катнашканнан соң, Байкал артына күчергәннәр иде, болай булса яңадан фронтка ташларлар инде.* З.Мурсиев

22) Халыкка яки аерым шәхескә берәр тәкъдим, теләк, хис, чакыру һ.б.ш. юллау, адреслау, шуны белдерү, шуның белән мөрәҗәгать итү. *– Син миңа багышлап эпиграмма чыгаргансың икән? – ди Ркаил, сораулы караш ташлап.* Р.Миңнуллин. *Элегрәк АКШ та А.Гайдамакны гаепләп чыккан иде. Израиль дә аңа гаепләр ташлады.* Ф.Фәтхи

23) Мәхрүм итү, берәр нәрсәдән калдыру, өлеш чыгармау. *– Сөбханалла, күзләрен ачты бит Хөснеҗәмалым, – диде Харрә, куанычыннан нишләргә белмичә. – Җә Раббым, рәхмәтеңнән ташлама.* М.Әмирханов. *Игелегеңнән, шәфкатеңнән ташлама, догаңнан аерма...* Г.Гыйльманов

24) *күч.* Теләмичә генә бирү, өлеш чыгару. *Үземне өрмәгән җиргә утыртмады, иясен яратсаң, этенә сөяк ташла, дигәндәй, күрсәтмәгән хөрмәте калмады.* Н.Яһүдин

25) *күч.* Каядыр әләгергә мөмкинлек бирү, туры китерү, форсат чыгару яки, киресенчә, мәҗбүр итү, дучар итү. *Җиңүгә дә күп калмаган иде бит, кем уйлаган язмыш дигәннәре немец әсирлегенә китереп ташлар дип.* Ф.Хуҗин. *Яңа гына өйләнешеп яши башлаган Хәлил белән Айсылуны язмыш иркен казак далаларына ташлады.* Г.Габидуллина

26) **ташла** Берәр килешмәгән, ярамаган, туйдырган эштән тыелырга, туктарга өндәү, кушу мәгънәсендә әйтелә. *Зинһар, дип әйтәм, шагыйрьләнүләрне, фәлсәфәләрне ташлагыз әле.* Г.Камал. *Берничәсенең өенә барып, ташлагыз бу эшегезне, соңгысы булсын, дип оялтмакчы, тәртипкә китермәкче булган идем, авыз ачарга да ирек бирмәделәр.* В.Нуруллин. *Ташлагыз алдашуыгызны, дим мин сезгә.* Д.Салихов

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Төп фигыльдә белдерелгән эш-хәрәкәтнең бик кискен, саксыз яки бик җәһәт, тиз башкарылуын белдерә. *Зәй, үзе дә абайламастан, эчендәген әйтеп ташлады.* Х.Камалов. *Кабан күленә Бауман урамыннан, күп булса, җәяүләп ун минутлык юл, аны үткәч, чишенеп ташлап, күңелләр булганчы су коендык.* Ф.Хуҗин

2) Төп фигыльдә белдерелгән берәр эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын, бер мәртәбә генә үтәлүен, кайтарылгысызлыгын белдерә. *Егетләр, түбәне каерып ташлагыз, түбәне!* Г.Әпсәләмов. *Ул авыру тештән фәкать суырып ташлап кына котылырга мөмкин.* М.Әмирханов

3) Төп фигыльдә белдерелгән эш-хәрәкәтнең артыграк, чамасызрак яки ялгыш булуын белдерә. *Зәки исә вакыт-вакыт шундый сүзләр әйтеп куя, шундый гамәлләр кылып ташлый, бетте бу, үзен харап итте, дип уйлыйсың.* Т.Миңнуллин

**Ташлап алу** Тиз генә ташлау. *Аз гына алгарак китеп, бераз барган саен туктап ял итүче Мөхәммәдьяр картка шикле-шөбһәле караш ташлап алсалар да, Сирин дә, Халисә дә юл буе бер авыз сүз эндәшмәделәр.* Г.Гыйльманов. *Шәраблы савытны кулына алгач, өй башлыгы табындашларына горуранә бер караш ташлап алды.* З.Мурсиев

**Ташлап бару** Рәттән, булган берен эзлекле рәвештә ташлау. *Кемдер алдан әзерләп, капчыкларга тутырып куйган бәрәңгене тәрәзәдән вагонга үрмәләгән Нәгыймь мышный-мышный, тирлитирли иптәшләренә ташлап барган иде.* А.Гыйләҗев. *Әйтерсең Казанның бөтен чүбен-пычрагын шунда ташлап барганнар.* Р.Юныс

**Ташлап бетерү** Барысын да ташлау; һәркем ташлау; бөтенләйгә ташлау. *Сату итәргә җае юк, дус-ишләр дә барысы да ташлап бетерделәр, берәр урынга керермен дигән идем.* Г.Камал. *Консерваторияне тәмамлагач, Мирсәетне М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына җырчы итеп алдылар. Әмма ансамбльне дә ташлап бетермәде.* Г.Гомәр

**Ташлап карау** Берәр нәтиҗәгә омтылып, сынау өчен ташлау. *Зур песиләрне Америкада унынчы каттан да*

*ташлап караганнар. Алар һәрчакны аякларына төшкәннәр.* А.Хәсәнов. *Дружиналарны ничәмә-ничә тапкыр штурмга ташлап карадылар, бертөрле дә файдасы күренмәде.* В.Имамов

**Ташлап кую** Кинәт, көтмәгәндә ташлау. *Сәрвәрнең вафатыннан соң нишләп әле Солтанъяр, күңел төшенкелегенә бирелеп, дингә аз игътибар бирә башлады? Хәтта Коръән ятлавын да ташлап куйган ласа.* З.Мурсиев

**Ташлап тору** Хәзерге моментта ташлау белән шөгыльләнү; даими яки әледән-әле ташлау; вакытлыча ташлау. *Аңа медицина режимына буйсынырга, ярсу йөрәген тыярга, иҗат планнарын бер якка ташлап торырга туры килде.* М.Хәсәнов. *Һади Маликов йөгереп килеп кергәндә, Мулланур иң соңгы кәгазьләрне утка ташлап тора иде.* Казан утлары

**Ташлый бару** *к.* **ташлап бару**. *Кирәк булмаган, гамәлдән чыккан нәрсәләрне тормыш үзе сызып ташлый бара.* Р.Батулла. --- *карлыган, чия төпләре дә – берсе дә калмады. Актарып ташлый барам, асылташ җыйган кебек, тамырларны җепселләренә чаклы җыеп ала барам.* М.Садыйков

**Ташлый тору** Әледән-әле, һаман ташлау; ниндидер башка эш белән бергә ташлауны да дәвам итү. *Мин таратып ташлый торам, Әбекәй җыйнап тора.* Ф.Яруллин. *Остаз саргаеп беткән китапларын, кульъязмаларын берәм-берәм утка ташлый торды.* Казан утлары

**Ташлый төшү** Тагын бераз ташлау. *Башлыйбыз. Бер! Хөбәйбә апа, аякларыңны читкәрәк ташлый төш. Ике! Сул аякка тезләнегез.* Т.Гыйззәт

**ТАШЛАШУ** *ф. урт. юн. к.* **ташлау**. *Таулар ауса да, Ташлар яуса да, Ташлашмабыз һич тә. Вәгъдәбезне айлы төннәр, җәйге көннәр, Искән җилләр, үскән гөлләр Төшереп торыр искә.* Ф.Яруллин. *Шөкер, очраклы вак нәрсәләргә зур игътибар биреп, алар араларны өзмәде: артык якын булмасалар да ташлашмадылар.* А.Хәлим

**Ташлашып алу** Тиз генә ташлашу; беразга, берара ташлашу. *Мөдир һәм кушчы төрекләр бер-берсенә аптыраулы күз карашлары ташлашып алдылар.* М.Галәү. *Сүз дә юк, бер-беребезгә шомлы караш ташлашып алдык.* Кызыл таң

**Ташлашып кую** Көтмәгәндә ташлашу

**Ташлашып тору** Берникадәр вакыт ташлашу; вакытлыча ташлашу. *Өч көннән артык бер-берсен ташлашып торучылар хаксызлык кылучылардан булырлар ---.* Р.Фәхретдин. *Төрле сораулы карашлар ташлашып, сүз тапмыйча ык-мык килеп торганнан соң, бермәлдә, ниһаять, икесенең дә телләре ачылды.* С.Поварисов

**ТАШЛЫ** *с.* 1) Билгеле сыйфаттагы яки сандагы ташы булган. *Дүрт ташлы зур тегермән урынында кайнар көл өеме генә торып калды.* М.Галәү. *– Кызым, кил әле, – дип, Данәгөл үз янына Радмиланы дәште. Рубин ташлы алкаларын, салып, аның колагына киертте.* А.Хәсәнов

2) Ташлары күп булган (җир тур.). *Әлбәттә, үләнсез-нисез ташлы җирдә ятуны ял итү дип әйтүе кыен иде, ләкин егетләр бу турыда уйлап та карамадылар.* И.Хуҗин. --- *туфрак һәр урында да бертөсле генә түшәлмәгән: кара җирләре бар, комлысы, арырак киткәч исә ташлы һәм чокырлы-чакырлы урыннары күбрәк очрый.* З.Хөснияр

**ТАШЛЫК** *и.* **1.** 1) Таш күп булган җир, ташлы урын. *Тау түбәсе – ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора.* Ә.Еники. *Кара җирдә ашлык уңа, ак җирдә ташлык була!* Ш.Галиев

2) Таш чыгару урыны, таш карьеры. *Нигә Усман ташы дип атаганнары аңлашыла, чөнки ташлык шул исемдәге авылдан ерак түгел ---.* Ә.Әминев. *Ташлык карьеры киң чокырдан гыйбарәт булып, бу елларны аннан таш чыгармаганга, ташу суы белән агып килгән комбалчыкка күмелеп бара.* А.Вергазов

3) Елганың ташлы төбе; елга агымында шундый ташлар күбрәк өелгән урын. *Монда комлык, вак ташлык, су бик чиста, хәтта бераз салкынрак та кебек.* Ә.Еники. *Кичтән ук Дон тамагыннан өстәрәк, Непрядва елгасы ташлыгы турында атлылар өчен кичү урыны билгеләделәр.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Ташлы булган; ташы күп булган. *Ташлык җиргә тары чәч.* Мәкаль. *Урам буе ташлык юл – Дагалы булсын атларың; Йөрәгем башын өзеп ала Кичә генә килгән хатларың.* Җыр

**ТАШЛЫ́К КӘҖӘСЕ** *и. зоол. к.* **тау кәҗәсе**; *русчасы:* **сибирский горный козёл**

**ТАШЛЫ́К КӨРТЛЕГЕ** *и. зоол.* Кыргавыллар семьялыгыннан җыйнак гәүдәле, кыска муенлы кыр тавыгы; киклек; *русчасы:* **куропатка каменная**

**ТАШЛЫ́К ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Чыпчык кошлар семьялыгыннан ачык ташлы җирләрдә яши торган, йорт чыпчыгыннан эрерәк гәүдәле кош; *русчасы:* **каменка**. *Ак башлы ташлык чыпчыгы. Биюче ташлык чыпчыгы*

**ТАШМАҢГАЙ** *и.* Үзсүзле, киребеткән, тискәре кеше; ахмак. --- *сәясәтчеләр дә, ташмаңгай генераллар да шушы хакыйкатьне һич тә аңларга теләмиләр.* Казан утлары

**ТАШПУЛАТ** *и.* Зур, бай торак йорт, сарай; гомумән, авыл йортларыннан аермалы буларак, таштан салынган зур бина. *«Лапетус» кунакханәсе – шәһәр үзәгендәге алты катлы ап-ак ташпулат.* Т.Әйди. *Ходаемның биргәненә шөкер! Кирәк түгел миңа ташпулат, Дандәрәҗә мине кызыктырмый, Һәм байлык та йөрмим мин сорап.* Аманулла

**ТАШ-ТАУ** *и. к.* **тау-таш**. --- *аңа кирәкле зур «ТУ» соры бетон тасманың иң аргы башында, очарга хәзерләнеп, инде борылып ята, аэродром өстендә, таш-тау җимерелгән сыман, каты гөрелте тавышы тетрәп тора иде.* М.Зарипов. *Аһәңле вә садә татар моңы! Ул әле сандугач булып сайрый, әле таш-тау арасыннан саркып чыккан иркә чишмәдәй челтер-челтер килә, әле саз кылы кебек сызлана.* Казан утлары

**ТА́Ш ТИБЕШЛЕ** *и.* Җиргә сызылган сызыклар аркылы төрлечә сикереп, шакмак тибеп уйнала торган балалар уены; сызыклы. *Балалар велосипедта узыша, балалар таш тибешле уйный, куышалар, йөгерешәләр.* Х.Ширмән

**ТАШУ** I *ф.* (таш, таша, ташар, ташачак) 1) Көчле явым-төшем, кар эрү һ.б.ш. сәбәпләрдән сулыктагы су югарылыгы күтәрелеп, ярларыннан чыгу,

гадәттәге агым юлын үзгәртү. *Яшел хәтфә булып уҗым җәйри, Ярларына сыймый сулар таша.* Н.Әхмәдиев. *Язлары башка иде. Ташулар да кайнабрак Ярлардан таша иде. Белмим, ничек – без яшь чакта Кояш соң бата иде.* В.Фатыйхов

2) Савытка берәр сыеклык тутырганда тулып яки кайнаганда кабарып, шуның эченә сыймыйча читкә агып чыгу. *Алайса, әйдә, чәй дә куйган идем, ташып ята торгандыр, кереп, башта чәй эчик, шунда сөйләшеп утырырбыз.* Р.Сәгъди. *Кирәк бит, шул чакта плитәдә аш ташып түгелә.* Э.Закирова

3) Эченә сыйдырмый башлау (савыт тур.). *Өйдә чиләк тулып ташкан. Улы юеш идәндә, көлә-көлә, нәни куллары белән суны чәбәкли иде.* Ф.Җамалетдинова

4) *күп.* Күп булып, массалы рәвештә каядыр чыгу (кешеләр тур.). *Теге вакытта җиңү яуланды. Халык урамнарга ташып чыкты. Гүя бәхеткә тиенгән иде бар да.* Ф.Җамалетдинова

5) *күч.* Хисләр белән тулу, нык дулкынлану, хискә бирелү; хисләр үтә көчле, тулы булу. *Бәхетем ташты. Кулларымны синең иңнәреңә салып туктаусыз биисем килде.* Ф.Яруллин

◊ **Ташып тору** Берәр нәрсә гадәттән тыш күп, мул булу. *Һәркемне әсир итәрлек серле күзләр. Озын буй. Көчгайрәте ташып тора.* С.Поварисов. *Урак бетүгә келәтләр ташып тора.* Р.Ханнанов

**Таша башлау** Ташырга тотыну. *Күңел дә нәкъ язгы ташулар кебек таша башлый.* Идел. *Ул чорда, билгеле булуынча (дөресрәге – рәсми мәгълүматлардан күренүенчә), кар катламы калын булып, ул бик тиз эрү нәтиҗәсендә, сусаклагыч тулып таша башлый.* Кызыл таң

**Таша тору** Даими рәвештә, өлеләнәле ташу. *Энергия анда һаман тулып таша торды.* Фәнни Татарстан

**Ташып алу** Аз гына вакыт арасында, бераз гына ташу. *Бу, мөгаен, бер мавыгу гына: Дуамалланып бер шашып алу, Ирештереп диңгез дулкыннарын, Ихтыярсыз ярсып, ташып алу!* Р.Миңнуллин

**Ташып бетү** Бик нык ташу; беткәнче ташу. *Сабир икмәк алып кайткач, самавыр куеп җибәргән булган идем, самавырым кайнап ташып беткәндер инде.* Г.Камал. *Хатын-кызның буасы ир аркасында ерылса, беттең дигән сүз: ачуы ташып бетеп, күңеле тәмам бушанмаса, аның тыелачагы да, аны тыяр көч тә юк.* А.Гыйләҗев

**Ташып килү** Акрынлап ташу; ташырга тору. *Коточкыч ялгышлык булган ул... Зиһене ачыла башлаган Сәгадәттә ярсу ташып килә иде.* С.Сөләйманова

**Ташып китү** Кинәт ташу, кисәк таша башлау. *Яшел тау битле, гомер агышын санап челтерәп аккан күп чишмәле, таллы-куаклы бу кояш илендә көннәрдән бер көнне ничек инде табигатьнең күңеле бер ташып китмәсен ди?* М.Мәһдиев. *Бер күрүем җитте – хис шашып китте, Дулкынланды уйтойгы, ташып китте.* Р.Гаташ

**Ташып тору** Хәзерге вакытта ташу; билгеле вакыт дәвамында ташу. *Өстеннән ташып торган сөтле чиләген күтәреп, елмаеп төшкән җанлы сурәтләре гәҗит битләрендә, хәтта кино кадрларында да күренгәләде.* Х.Ибраһим

**Ташып чыгу** Нык ташу, чамадан тыш ташу. *Сабый, --- ташып чыккан куанычыннан теле бәйләнеп, баш кагып кына җавап бирде.* М.Шабай. *Әмма бу юлы әтинең, җанашымның, ачуы тәмам ташып чыккан.* А.Хәсәнов

**ТАШУ** II *и.* Ташкын күренеше. *Вакытында төзәтеп куярга куллары җитмәде, икенче елда язгы ташу буаның субайларын, тегермәннең куласаларын кырып, чөйләре-ниләре белән агызып китте.* А.Гыйләҗев. *Ташу вакытында тагаракларга су тула да, коедан ташып йөрисе булмый ---.* М.Яһудин

**ТАШУ** III *ф.* (ташы, ташый, ташыр, ташыячак) 1) Даими рәвештә йөкләрне җибәрүчедән алучыга, төяп алган урыннан тапшырыласы, бушатыласы урынга күчереп тору. *Сарыкларга суны әлегә машина белән ташып эчертәләр.* А.Хәсәнов. *Без менә дүртенче көн кырдан базга кукуруз ташып, силоска салабыз.* Н.Әхмәдиев

2) Кемгә дә булса даими рәвештә яки еш кына берәр нәрсә бирү; тарату, өләшү. *Үз бакчасыннан алмасын, чиясен ташып ашату дисеңме, төрле чәчәктер, яфрактыр алып килеп, аларның ничек үсүләрен аңлату дисеңме – аңардан берсе дә калмый.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Бер кеше сүзен (гадәттә – начар ният белән) икенчесенә сөйләү, җиткереп тору, гайбәт тарату. *Ни эшләп әйтим, Алла сакласын. Сүз ташып йөрергә мин Чулак Фатыйма түгел ич.* К.Тинчурин. *Урамнан сүз ташу гадәтеннән ваз кичтерергә иде шуларны.* Р.Гаязетдин

**Ташый башлау** Ташырга керешү. *Шул көннән башлап бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар, ә шөпшәләр, ялкаулыклары аркасында, хурлыкка калганнар.* А.Алиш. *Бәрхет тышлы урындыкларны ташый башлагач, Таймас, таш идәнгә тезләнеп, нәрсәдер эзләргә тотынды.* А.Тимергалин

**Ташый тору** Акрынлап ташу; берәр эш-хәлгә кадәр, әлегә ташу. *Уртада өелеп торган туфракны һәм кирпеч ватыкларын, уч белән генә чиләкләргә тутырып, Сафуанов һәм Таймас янына ташый тордылар.* А.Тимергалин

**Ташып бетерү** Ташуны тәмамлау; барысын да ташу. *Бүлмәңдә китапларың бигрәк күп бит, ничек ташып бетерерсең инде, дип борчылдым...* Р.Миңнуллин. *Урылган, киптерелгән иген чүмәләләрен яңгырга кадәр ничек ташып бетерерләр соң алар?* Г.Гыйльманов

**Ташып бирү** Башка берәүләр өчен ташу. *Материалларны колхоз хисабына ташып бирәбез.* Р.Миңнуллин

**Ташып йөрү** Ташу эше белән шөгыльләнү; әле ташу. *Нурулла абыйның электр станциясе бүрәнәләрен ташып йөргән кара йонлы атының артиллерия хезмәтенә алыну хәбәрен ишеткәч, без өнсез калдык.* Т.Нурмөхәммәтов. *Хатыннар өстәлгә ашамлыклар, эчемлекләр ташып йөриләр.* Э.Яһудин

**Ташып калу** Үз вакытында, берәр форсаттан файдаланып ташу; ташырга өлгерү. *Урманда делянка биргәндә ташып калмасаң, башка колхозларга бүлә башларлар.* Ф.Яруллин. *Юллар катты, шомарды, бураннар башланганчы, кирәкяракны күбрәк ташып калырга кирәк, ә бураннар көттермәс, октябрь азакларында ук котыра башлар.* С.Шәрипов

**Ташып карау** Сынау өчен ташу. *--- иптәшләрең шау-гөр килеп уйнап йөргәндә, көтү кайткан вакыттан*

*алып караңгы төшкәнче, кечкенә арбага җигелеп, сәгатьләр буе тау астыннан су ташып кара әле!* Г.Бәширов. *Чана тартып, симәнә ташып кара әле син, ә?* Ф.Җамалетдинова

**Ташып кую** Алдан ук хәстәрен күреп ташу; тиз арада ташу. *Кошчак олан карт качыры белән камыш, кизәк ташып куйды.* Р.Батулла. *Юл өзелгәнче пилорамын, башка нәрсәләрне ташып куярга кирәк...* З.Мурсиев

**Ташып тору** Даими, һаман, һәрвакыт ташу; әле ташу. *Уналты яшьлек үсмер Каюм чәй коелган чынаякларны чаршау эченнән түр якка ташып тора икән.* М.Кәрим. *Өчтерсәк Хәсән бер-өзлексез ат белән йөреп, тиешле кешеләрне ташып торды.* Н.Яһудин

**Ташып яту** *сөйл. к.* **ташып тору**. *--- олыдан кубып мәктәп төзи башлаганнар, клуб һәм дәвахanә салу өчен агач ташып яталар.* З.Мурсиев

**ТАШЧЫ** *и.* 1) Таш чыгаручы, таш кисүче, таш карьеры эшчесе. *Атна дигәндә Болгардан йөзләгән ташчы килде, һәм алар килү белән таш чыгара башладылар.* М.Хәбибуллин

2) Төрле корылмалар төзегәндә таш, кирпеч һ.б.ш.лар белән бәйле эшләрне башкаручы эшче. *Әнә ташчы егетләр, кельмаларын ялт-йолт уйнатып, ак силикат кирпечләрне берәмтекләп тезә баралар.* Н.Хәсәнов. --- *ә Тәфкил – ташчы, ачык һавада көне буе аягөсте кирпечләр тезә.* Ф.Абдуллин

3) Юлга таш каплама ясаучы, таш түшәүче. *Иреккә илтүче юлларны тигезлә! Азатлык! Ташчы егет! Күтәр башкаеңны, Авыр ташларыңны куеп тор.* Р.Әхмәтҗанов

4) Таш эшкәртүче, таштан төрле кирәк-ярак яки сәнгать әсәрләре ясаучы. *Татарстанның Минзәлә районында Югары Тәкермән авылында ташчы, сөяктән, агачтан бизәкләр, сувенирлар, көнкүреш җиһазлары эшләүче Альбина Әхмәтшина яши.* Р.Исхакый

**ТАШЧЫЛ** *с.* 1) Ташлы (*2 мәгъ.*)

2) *биол.* Ташлар арасында яши, ташка оялый, ташта үсә торган (үсемлек яки хайваннар тур.). *Ташчыл үрчем*

3) *биол.* Күренеше ташны хәтерләтә торган. *Механик тукыманың ныклыгын белү өчен, сез әстерхан чикләвегенең, абрикосның каты төшләрен ватып карагыз: аларда махсус ташчыл күзәнәкләр була.* Н.Сонин. *Ташчыл нерв. Ташчыл синус*

**ТАШЧЫЛЫК** *и.* Ташчы һөнәре; ташчы эше, шөгыле; ташчы осталыгы. *– Боларның ташчылыгын пәригә үлчим менә... – Хатын читтә тәмәке суыручы ирләргә ишарәләде.* С.Зыятдинова. *Фундаментның да, ташчылыкның да, дизайнның да ни икәнен беләм хәзер.* Шәһри Казан

**ТАШЧЫПЧЫК** *и. зоол. к.* **ташлык чыпчыгы**

**ТАШЪЯЗМА** *и.* **1.** Берәр язуы булган таш, гадәттә борынгы язма истәлек. *Бу ташъязма турында моңарчы басылган бер мәгълүмат та тапмадык.* Безнең мирас

**2.** *с. мәгъ.* Таш өстенә язылган. *Казан ханлыгы чорындагы тарихи ташъязма ядкәрләр – шанлы елларның моңсу шаһитлары.* Гасырлар авазы. *Үзәктә алып барыла торган эшчәнлекнең тагын бер юнәлеше – ташъязма истәлекләрне өйрәнү.* Безнең мирас

**ТА́ШЪЯРГЫЧ** *и. бот. к.* **ташкыран**

**ТАШЫНУ** I *ф.* 1) Бик нык ташу, ургылып-ургылып ташу. *Сикреп-сикреп ага кар сулары, Ермаклардан ага ташынып, Шул сулардай үткән гомеремне Искә алам хәзер ачынып.* Ш.Галиев

2) *күч.* Нык ярсу; хисләр үтә көчле чагылу. *Ташынган күкрәгем зур омтылыш, ялкынлы дәртләрдән. Йөрәк кайный тулып диңгез кадәр көчле теләкләрдән.* Н.Исәнбәт. *Тик язып өлгер: ташыр бер, ташынып килер җырлар!* Р.Гаташ

**Ташына бару** Торган саен ныграк ташыну

**Ташына башлау** Ташынырга тотыну. *Ни гаҗәп, мәҗлеснең әнә нәкъ шул вакытында: җырлыйсы, биисе килеп күңел ташына башлаган вакытында гына сөйләргә теләүчеләр кыза.* М.Мәһдиев

**Ташына тору** Берәр эш-хәлгә кадәр ташыну

**Ташынып бетү** Тәмам ташыну, нык ташыну

**ТАШЫНУ** II *ф.* 1) Күп әйбер белән бер урыннан икенче урынга бару; үз әйберләреңне бер урыннан икенче урынга ташу, күчерү. *Ничек кенә булмасын, күтәренеп-ташынып, кояш нурларын яңа ут позициясендә каршыладылар.* С.Поварисов. *Сәмигулла абзый яңа йортка күчүне тиз тотты. Ташыну үзе генә шактый мәшәкатьле булып чыкты.* М.Шәрифуллин

2) Бер яшәү урыныннан икенче урынга бөтенләй күчү; күчену. *– Күрче, – диде, – таш гасырдан алып Бар гүзәллек монда ташынган.* Р.Әхмәтҗанов

**Ташына тору** Акрынлап ташыну; берәр эш-хәлгә кадәр ташыну. *Бер көн вакыт бирелгән иде, без өч көн, өч төн ташына торгач, андагы бинага килеп егылдык.* Кызыл таң

**Ташынып алу** Азга гына ташыну; тиз генә ташыну

**Ташынып бетү** Ташыну эшен тәгәлләү. *Ташынып беткәч тә, мин 25 ел гомер иткән квартирымның ачкычларын Язучылар берлегенә илтеп бирдем.* Ә.Еники

**Ташынып йөрү** Ташыну эше белән мәшгуль булу; әле анда, әле монда ташыну. *Җыенып, ташынып йөрү, бигрәк тә үзен бик кадерләп тота торган бүлмә хуҗалары белән көрешеп китү мәсьәләләре аны борчый башлады.* Ф.Әмирхан

**Ташынып кую** Алдан ук ташыну хәстәрен күрү; тиз генә, тиз арада ташыну

**Ташынып тору** Ташыну эшендә булу

**ТАЮ** *ф.* 1) Берәр җирлеккә басканда, таянганда, нәрсәдер куйганда, таяну ноктасы тотрыксыз булып, тигезлекне югалту, шуып, ихтыярсыз рәвештә бер якка авышу. *Баскычта таеп егыла яздым, кемдер тотып калды.* И.Салахов. *Кая, чиләгеңне үзем алыйм, тая күрмә.* Д.Каюмова

2) Шома булу сәбәпле таянган өлектән шуып китү, җирлектә нык тормау. *Аларның күн итекләре тая, һич йөгерә алмыйлар.* Р.Батулла. *Юеш үләндә тире башмаклары тая.* Р.Сәгъди

3) Тиешле урыныннан, тупсасыннан, уемыннан чыгу, кузгалу; тайлыгу. *Машина тәрәзәсенең ватыклары тиеп, ике җирдән баш тиресе суелган да кулбашы таеп чыкканые.* В.Нуруллин. *Шулай да, егылып, кайсының бите сыдырыла, кайсының бармагы тая.* Г.Рәхим

4) Авышу, иелү, янтаю. *Өч таган таймас.* Мәкаль

5) Бер яккарак, кырыйгарак китү, тайпылу. *Ул, болар яныннан бер читкәрәк таеп, эчтән генә балдызын күз алдына китереп уйланып йөри башлый.* Х.Камалов. *Мәсәлән, фельдфебель --- акыра башласа, Мәүлетдин аның яныннан ераграк китәргә кирәклекне аңлап ала да читкәрәк тая.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Билгеле максатка, мәсләк, припцип һ.б.ш.га хыянәт итү, шуннан баш тарту, ваз кичү, читкә тайпылу. *Гаепләнүче үз әйткәненнән читкә таймады.* Г.Ибраһимов. *Антыбыздан читкә тайсак без бер генә, Безне суксын инкыйлабның иң каһәрле куллары.* Н.Исәнбәт

7) *күч.* Бик тиз, ашыгыч рәвештә китеп бару. *Шул арада кучкардан бүлмә ачкычын алып, миңа күзен кысып, ул өйалдына тая.* М.Мәһдиев. *Тукта, кай арада чыгып тайды әле Гөлүзә апасы?* Ф.Яруллин

8) *күч.* Бик тиз качып китү, шылу, ычкыну. *Өчкә хәтле саныйм, чыгып таймасагыз үзегезгә үпкәләгез, мәлгуньнәр!* Ф.Дәүләтбаев. *Тизрәк чыгып таймаган очракта, ресторанnан тимер беләзекләр белән чыгып китүебез дә ихтимал иде.* З.Мәхмүди

9) *күч.* Дөрес юлдан язу, ялгышу, хаталану; уңышсызлыкка юлыгу, бәлагә тару. *Таеп карамаган танып белмәс, ди. Хатасын аңлар, иншалла.* М.Хәбибуллин. *Безнең арттан барсагыз таймассыз, хе-хе.* Н.Гыйматдинова

10) *күч.* Гадәти физик яки рухи халәттән чыгу, берәр сәләтне, көчне һ.б.ш.ны югалту. *Мескенем, таеп хуштан, Чәчрәп төште баскычтан Бу юлларның авторы.* Г.Афзал. *Йөгерәчаба, хәлдән тая, җаны чыгар дәрәҗәгә җитә, әмма институтны таба алмый.* М.Хәсәнов

**Таеп алу** Аз гына таю. *Хәтта кызының кулын да, аягы таеп аламы, баскычтан төшкәннәрендә булсын, беренче булып килеп тотарга ашыкмады һәм уйламады.* Ф.Яхин

**Таеп бетү** Барысы да таю; тәмам таю. *Мин Гыйззетдин абзый кызы Мәрьямне куа-куа хәлдән таеп беттем.* Ә.Еники. *«Үзе» – Казанда, ә ул югында вак-төяк җитәкчеләр төрле якка таеп бетә.* Ф.Яруллин

**Таеп китү** Кисәк таю. *--- аш-су бипеп торучы Гасәбә туташ ялгыш таеп китте дә кулындагы тәлинкәсен төшереп ватты.* М.Әмирханов. *Кинәт кызның аягы таеп китте, һәм ул таш өстенә ава башлады.* З.Мурсиев

**Таеп кую** *к.* **таеп китү**

**Таеп тору** Беразга таю. *Бу хәбәр воеводаның йөрәгенә тигәнәк булып кадалды, истән таеп торды, хәтта кулындагы бокалы төшеп ватылганны да сизмәде.* М.Әмирханов

**Тая бару** Торган саен тагын да ныграк таю; бер-бер артлы барысы да таю

**Тая башлау** Таерга тотыну. *Клараның әледән-әле аягы тая башлады, хәтта ара-тирә артка таба шуып та киткәләде.* Ә.Еники. *Керем читкә күп тая башлады.* Ә.Хәсәнов

**Тая төшү** Бераз таю

**ТАЯК** *и.* 1) Беләктән нәзек, бармактан юан, чагыштырмача төз озынча агач кисәге; *русчасы*: **палка**. *Ашардай булып, каш астыннан сөзеп карыйлар. Куллары йодрыкланган, кайсы таш, кайсы таяк тоткан.* Л.Зөлкарнәй. *Мин аның янында кулыма кисәү агачы итеп таяк тоткан хәлемдә утырам.* Ф.Яхин

2) Шуңа охшаш теләсә нинди материалдан ясалган, гади эш коралы яки берәр эш җиһазының өлеше булып хезмәт иткән озынча предмет. *Тимер таягыннан тотып, кечкенә бөҗрасын өскә таба шудырсаң, чатыр киңәя, кабара, бөҗраны аска төшерсәң – җыела.* Н.Фәттах. *Бер кулында кармак таягы, иксенчесендә кечкенә генә зәңгәр чиләк.* Г.Сабитов

3) Шуңа охшаш әсбапның аерым эшләрдә, очракларда кулланыла торган махсус төре. *Әнә сыңар чаңгы таягы аунап ята, сынык бөҗрасы да янында гына.* А.Тимергалин. *Равил Фәйзуллин бильярд таягын кулга алуга, шарлар, бүредән өреккән сарыклар шикелле куырылып, бер тирәгә өелешә.* М.Галиев

4) Олы кешеләр таянып йөри торган (сирәгрәк – дин әһелләре һ.б.ш.ларның махсус билгесе булган), чама белән кеше буендагы әйбер; аса; *русчасы:* **посох**. *Башына ак чалма ураган, өстенә яшел чапан кигән, кулына озын таяк тоткан Шәмси мулла, мәзинне ияртеп, уенчылар бакыр акчаларын калдырып качкан төшкә таба китте.* М.Галәү. *Карт таякка таянган, сул кулын каш өстенә куйган, бөтен гәүдәсе суыктанмы, каушауданмы дер-дер килә иде.* А.Гыйләҗев

5) Авырткан аякка көч килмәсен дип таянып йөрү өчен, башында кул югарылыгында махсус тоткасы булган таянгыч. *Яралануы хак булгандыр, бер аягына аксап, кәкре башлы таяк тотып йөри иде.* Г.Галиев // Шуның аксессуар буларак ирләр куллана торган, еш кына сырланган, бизәлгән төре; *русчасы:* **трость**. *Европача киенгән бер кеше таяк тотып узып бара.* Г.Камал. *--- фин кепкасы киеп, сөяк таяк тоткан Леонид Соболев, төлке толып кигән Шаляпин --- – бөтенесе бергә урам уртасыннан баралар һәм миңа карап елмаеп, кул болгыйлар иде.* М.Мәһдиев

6) Сугу, бәрү өчен кулланыла торган гади корал; күсәк, суел; *русчасы*: **дубинка**. *Әмма башына резин таяк белән сугуга ук сыгылып төшмәде ул. Соңгы чигенә кадәр көрәшергә булды.* А.Хәсәнов

7) Югары дәрәҗә, хакимият, берәр оешма һ.б.ш.ның билгесе буларак кулда йөртелә торган, гадәттә сырлы, бизәкле озынча әсбап; *русчасы*: **жезл**. *Волхов фронтында батырлык күрсәткән солдатларын бүләкләр өчен, фашист командованиесе сырлап эшләнгән махсус таяк та уйлап чыгарды.* Г.Әпсәләмов

8) *иск.* Билгеле озынлыктагы агач кисәгеннән гыйбарәт озынлык үлчәү өчен гади әсбап. *Сәләхинең кулында җир үлчи торган таяк.* Р.Ишморат. *Авылыңа кайтасың, ишегалдында кемнәрдер йөри, үлчәгеч таяк тотканнар, бер сотка җирең артык икән, шуны кисеп, киртәңне күчерттерәләр ---.* М.Мәһдиев

9) *иск.* Элек җир кишәрлекләрен үлчәгәндә кулланылган озынлык берәмлеге; сажин. *Уракчылар кишәрлекләрен биш-алты таяк буе урып, берничәшәр өем куйгач, Габделкаюм да көч-хәл белән беренче көлтәне бәйли.* М.Гали

10) *иск.* Җир кишәрлегенең мәйданын үлчәү берәмлеге; квадрат сажин. *Исән-сау котылсам, үзем үлгәнче һәр елны Гайни карчыкка ун таяк тары чәчеп бирермен.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Кыйнау, суктырудан гыйбарәт тән җәзасы. *Унбиш таяктан соң тоткынның бары тик ыңгырашуы гына ишетелә башлады.* Г.Әпсәләмов

12) *күч.* Исемлектәге, пландагы берәр эшнең эшләнүе турында куелган шартлы билге. *Таякка эшләгән авыл кешесе шәһәрдә бирелгән тиеннәргә бик риза иде.* Т.Миңнуллин // Эшнең нәтиҗәлелеген билгеләүдә формальлек. --- *«палка» дигәннән, исем үзгәртеп кенә полициядә таяк системасы бетмәгән икән.* Н.Вәзыйхов

◊ **Таяк алу** Тән җәзасына тартылу, таяк белән суктырылу, кыйналу. *Барабан таяк ала, барабанчы акча ала.* Мәкаль. --- *фәлән номерлы тоткын фәлән гаебе өчен фәлән хәтле таяк алды, дип рапорт бирергә тиеш иде.* Г.Әпсәләмов. **Таяк астында** Теләмичә, риза булмыйча, көч белән мәҗбүр ителеп, көчләп. *– Болай таяк астында эшләргә мин кол түгел! – дип, контурадан чыгып китмәкче булган.* Ш.Усманов. **Таяк ашау** *к.* **таяк алу**. *Шайтан бер ел буе шулай таяк ашагач, солдат кире әйләнеп кайткан, ди.* Әкият. **Таяк ике башлы булу** 1) «Кешенең усаллыгы, эшләгән явызлыгы үзенә кайтырга мөмкин» мәгънәсен белдерә. *Таяк ике башлы була бит! Беләсең ич, Себер юлы тап-такыр. --- синең өстеңә дә шәп кенә тамызып була бит, Йосыф!..* Г.Бәширов; 2) «Теләсә нинди яхшы әйбернең дә начар ягы булырга мөмкин» мәгънәсендә әйтелә. *Таяк ике башлы шул: бер башы файда китерсә, икенче башы зыян салды.* Ф.Яруллин. **Таякка калу** 1) Хәлсезләнү, сәламәтлек нык какшау. *Коммуна, коммуна дип йөри торгач, таякка калдыңмыни?* Чулпан. *Хәсән абыйның сәламәтлеге бик начарланган, таякка калган икән, дигән хәбәр таралган иде ул вакытта.* М.Макаров; 2) Төрле яктан бирешү, артка китү. **Таякка таяк ялгау** Бик күп һәм оста, ышандырырлык итеп ялганлау, ялган өстенә ялган сөйләү. *Хөсәен абзый, өстемә кырык потлы снаряд төшеп аягымны өзде дип, таякка таяк ялгарга тотынган.* Г.Мөхәммәтшин. **Таякка таяндыру** Бөлдерү, хәерчелеккә чыгару. *Сез бит бергә эш итәсез, сез, минем колхозны таякка таяндыру өчен, немецлар белән берләшкәнсез!* Ф.Садриев. **Таякны бөгү** Берәр нәрсәдә артыгын эшләп ташлау, чаманы югалту. *Алмаз Әхәтович, әйдәгез, таякны бөгеп җибәрми генә сөйләшик.* Ә.Сәйфетдинов. *Шаукымлы, буталчык, ата – улны, ана кызны беләсе түгел көннәр. Таякны бөгеп сындырып ташлаулары да бар.* З.Нури. **Таякның авыр башы** 1) Берәр эшнең иң авыр өлеше, кыенлыгы. *Мин олырак булгангадыр инде, таякның иң авыр башы миңа төште.* Аманулла; 2) Берәр нәрсә өчен җаваплылык, җәза, шелтәнең төп өлеше. *Киңәшмәдә таякның авыр башы иң беренче чиратта әлеге дә баягы Кудрявцевка эләкте.* В.Имамов. **Таякның башы** *к.* **таякның авыр башы**. **Таякның юан башы** *к.* **таякның авыр башы**. *Мондый мәҗлесләр, тамашалар хатын-кыз өчен аерата болгавыр, баш бутагыч була, ни әйтсәң дә без, ирләр, ашыйбыз да качабыз, дигәндәй, таякның юан башы хатын-кыз җилкәсенә төшә.* А.Гыйләҗев. *Таякның юан башы бигрәк тә кызларга төшә, ата-аналарның бу кырыслыгыннан күбрәк алар җәфа чигә.* З.Хөснияр. **Таяк ору** Таяк белән сугу, кыйнау. *Ерак киявнең башына чатыр корыр, йорттагы киявнең башына таяк орыр.* Мәкаль. *Шәригать буенча хәзер йөз таяк орып, шул бурычым белән алтынымны алып бирегез, тәкъсир.* Н.Исәнбәт. **Таяк тию** *к.* **таяк төшү**. *Күп сүз аркаңа таяк тидерер.* Мәкаль. *Анда дингә бәйле һәркемгә таяк тими калмаган.* Безнең гәҗит. **Таяк тоту** Шобага тоту. **Таяк тотышу** *к.* **таяк тоту**. *Хәзер мин сине җиргә сеңдерәм бит, элек таяк тотышыйк әле, кайсыбызга беренче сугарга чыгар, ди.* Әкият. *Ләкин алдан ук әйтеп куям: кунак кыз миңа да ошаса, таяк тотышабыз. Кем өскә чыкса, кызны шул озата.* В.Нуруллин. **Таяк төшү** Берәр эш-гамәл өчен җавап бирү, җәза күрү. *Кеше башын басма итеп Менәләр чоңгылдан да. Таяк төшә гомер буе Гамьнәрдән басылганга.* Ә.Ситдыйкова. *Тик тегеләргә нинди җәза эләгер, белмим, ә минә минем башка таяк төшәсе хак.* Казан утлары. **Таяк тыгу** *к.* **тәгәрмәчкә таяк тыгу**. *Ярдәм итәсе урында, киресенчә, таяк тыккан очраклар шактый.* З.Мансуров. **Таяк тыккан кырмыска оясы кебек (төсле, шикелле)** Халык арасында дулкынлану, борчылу, бәхәс, ыгы-зыгы, шау-шу барлыкка килү турында. *Ә ике атнадан авыл таяк тыккан кырмыска оясыдай тузгый, кайный башлады.* Ф.Зариф. **Таяк тыккан умарта оясы кебек (төсле, шикелле)** *к.* **таяк тыккан кырмыска оясы кебек**. *Бүлмә эче таяк тыккан умарта оясы төсле гөж килде.* К.Тинчурин

**ТАЯКЛАП** *рәв.* 1) Таяк (*8 мәгъ.*) белән үлчәп, таяк (*9 мәгъ.*) белән исәпләп, таяк (*9 мәгъ.*) санынча. *Ә безнең монда таяклап бүләләр җирне, ул да җитми...* Ә.Фәйзи

2) Билгеле таяк (*10 мәгъ.*) чамасы. *Һәр кеше үзенә тигән җиргә берничә таяклап бүлеп-бүлеп чәчелгәнлектән, иген басулары нәкъ корама юрган шәкелен алып торалар.* М.Фәйзи

**ТАЯКЛА́У** *ф.* 1) Таяк белән кыйнау; таяк җәзасы бирү. *«Тот, җибәрмә, тот, үтер!» – дип, каравылчылар таяклап үтерделәр [этне].* К.Насыйри. *Этләр янына килсә, этләр сырты белән тора моңа, кешеләр янына килсә, таяклап җибәрәләр, бүреләр янына тәпиләсә, кабыргаларын кимерә-кимерә талыйлар.* Сабантуй

2) *иск.* Таяк (*8 мәгъ.*) белән үлчәү; таяк (*9–10 мәгъ.*) белән исәпләү

3) *күч.* Мәҗбүр итү, көчләү. *Хәлимнең прокурорны ярсытасы килмәде, каты бәрелмәде, Ленинның, урта крестьянны таяклап социализмга алып барып булмаячак, дигән сүзләрен китерде.* И.Гази

4) *күч.* Бик каты ачулану, куркыту. *Бер карчык Юляны хәтта куган таяклап. Ярый ял итүче берәү өлгергән яклап!..* Р.Харис

**Таяклап алу** Аз гына таяклау; тиз генә таяклау

**Таяклап бетерү** Таяклауны тәмамлау; бик нык таяклау

**Таяклап карау** Таяклау чарасын сынау. *Башта аз гына сизенсә дә, бик нык кыйнап, таяклап карады, ләкин тыя алмады, егетләр, туры килгәндә, өмәдә, калага барганда, ара-тирә төшергәли торган булдылар.* Г.Ибраһимов

**Таяклап тору** Әле таяклау; даими яки әледән-әле таяклау

**Таяклый бару** Рәттән, эзлекле рәвештә таяклау

**Таяклый тору** Әледән-әле таяклау. *Без килен чакта, кайнатай мәрхүм --- синең анаңны авызлыклый, таяклый торды.* Г.Ибраһимов

**Таяклый төшү** Тагын бераз таяклау

**ТАЯКЛАШУ** *ф.* Таяклар белән кара-каршы сугышу. *Берен бере ислах кылып кую түгел, Кызынкырап киткәндә таяклашу. Камилнең кәмаленә инкяр кылып, Түбәләшмәй басылмай безнең ачу.* М.Акмулла. *Сәңа хаҗәт түгел хаслап, ачыг берлән сүзең башлап, Күтәреп кул таяклашмак, әйдәмәк фетнәи һәйхәт ---.* Һ.Салихов

**Таяклаша башлау** Таяклашырга тотыну

**Таяклашып алу** Бераз, берара таяклашу

**Таяклашып тору** Әле, хәзер таяклашу

**ТАЯКЛЫ** *с.* Таяк тоткан, таякка таянган. *Гөрләгән йортлар зәгыйфь калган таяклы карт кебек, Иске рәхәтләр авылга күрнә инде ят булып.* Ф.Ибраһимов

**ТАЯКЛЫК** *и.* **1.** Таяк ясарга ярарлык яки таяк ясауга китә торган агач

**2.** *с. мәгъ.* 1) Таякка ярарлык. *Таяклык агач*

2) Билгеле таяк (*10 мәгъ.*) мәйдан тәшкил иткән; билгеле таяк (*9 мәгъ.*) озынлыгындагы. *Өч бөртек кеше, әлеге шул уналты таяклык җиребездән көтеп, елның уңышлы килүенә куана-куана, бер-беребезгә береген торасы бер вакытта, без тагын бер кешебезне озаттык.* Ф.Хөсни

**ТАЯКСЫЗ** *с.* **1.** Таягы булмаган; таякка таянмаган. *Бер сөрлегүендә, ул чак кына егылмады, Халисә аның таяксыз кулыннан култыклап алды.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Таяк ярдәменнән башка гына, таякка таянмыйча. *Аягы төзәлә төште, таяксыз йөри башлады.* М.Хуҗин. *Таяксыз йөри алмый инде хәзер: тыны каба, сулуы кысыла...* Ф.Җамалетдинова

2) Таягы булмый торып, таяк белән коралланмыйча. *Әмма соңыннан: «Юаш эт янына таяксыз барырга ярамаганлыкны аңласын, әйдә, бу хәчтерүш!» – дип уйлады.* С.Поварисов. *Мин, Иске Алат малае, шушындый зур сәфәргә кармаксыз-таяксыз, буш кул белән чыгаммы инде ---.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Мәҗбүр итмичә; көч, җәза кулланмыйча. *Сез моңарчы таяксыз да төшендерә белә идегез.* Ә.Баян

◊ **Таяксыз нуль** Шәхес буларак, белгеч буларак һ.б.ш. яктан буш, ихтирамга лаек булмаган кеше. *Шул киң аркадан, тыгыз муеннан башка үзенең эче буш клиндер, таяксыз нуль икәнен аңларлык кына сиземләү сәләте бар иде аңарда.* Т.Галиуллин

**ТАЯ́К ТАРТЫШ** *и.* Бер таякка ике яктан тотынган хәлдә аякларны терәшеп, бер-береңне урта сызыктан үз ягыңа тартып чыгарырга тырышудан гыйбарәт уен

**ТАЯ́К ТАРТЫШЛЫ** *и. к.* **таяк тартыш**. *Аштан соң кул чабышлы, таяк тартышлы уеннары булды.* А.Таһиров

**ТАЯКЧЫ** *и. сир.* Сукырны җитәкләп йөрүче кеше. *[Гайшә:] Әйдә, бабай, мин карт көнеңдә синең таякчың булырмын.* Ф.Бурнаш. *Таякчы – сукыр кешене җитәкләп йөртүче, ягъни аңа таякны алмаштыручы (русча – поводырь).* А.Тимергалин

**ТАЯКЧЫК** *и.* 1) *махс.* Кечкенә таяк формасындагы махсус әсбап. *Халыкара хәлләр лекторы стенадагы кадакка дөнья картасын элеп куйды да, очлы башлы, нәзек күрсәткеч таякчык белән уйнаган сымак хәрәкәт ясап, ачык, көр тавыш белән кәгазьсез-нисез сөйли башлады.* Г.Афзал. *Нәфис дирижёр таякчыгы винтовка очындагы штыктан да куәтлерәк иде бу минутларда.* Р.Низами. *Санау таякчыкларымны да онытып калдырмадым.* Р.Хәтимова

2) *махс.* Формасы белән озынча туры таякка охшаш бактерия төре; бацилла. *Туберкулёз белән авыручыларны дәвалаган табибларның Кох таякчыкларын үзләренә йоктыру очраклары сирәк.* А.Хәсәнов

3) *анат.* Кешедә һәм умырткалы хайваннарда күзнең челтәр катлавындагы, озынча туры таякка охшаш формалы, яктылыкка сизгер күзәнәк

4) Кайбер ризыкларның кечкенә таяк, чыбык формасында ясалганы. *2 төргәк йомшак сыр, ике тырнак сарымсак, 5–6 краб таякчыгы, әстерхан чикләвеге, майонез кирәк.* Мәдәни җомга. *Аларны күргән саен, башымда мең төрле сорау бөтерелә: --- әйбәт түлиләрме икән, товарларын алучылар бармы, нигә нәкъ менә кукуруз таякчыгы сатарга булганнар?* Шәһри Казан. *Балык таякчыгы*

**ТАЯНГЫЧ** *и.* 1) Баскыч, болдыр һ.б.ш.ларның читендәге култыкса. *Урындыкның ул биек аркасына сырлапуеп матур-матур чәчәкләр, бизәкләр ясалган. Ул таянгычлары, аяклары да бормалы-сырмалы бизәкле.* Р.Төхфәтуллин. *Бер кулы белән болдыр таянгычына тотынган көе ул янә аваз салды ---.* Ф.Җамалетдинова

2) Култык таягы. *Таянгыч ярдәмендә йөрүче әбекәй өчен бу, чыннан да, зур вакыйга.* Бөгелмә авазы

**ТАЯНУ** *ф.* 1) Гәүдәнең авырлыгын берәр нәрсәгә салу. *Көрәгенә таянган хәлдә, кайчандыр колагына чалынган бер юләр мәзәкне дә исенә төшереп, авыз чите белән генә елмайгандай итте.* А.Хәлим. *Уң аягына таянмаска тырышып, башта кулларын, аннан сул аягын алга шудырды.* М.Кәбиров

2) Гәүдәнең авырлыгын өлешчә кулга яки кул белән тотынган нәрсәгә күчерү. *Йөгереп үк булмаса да, җитез генә, минем сузылган кулыма таяныр-таянмас кына сәхнәгә менде ул.* Р.Кәрами

3) Кулны гәүдәнең бер җиренә терәп тору яки терәк итеп кую. *Нуров, тезләренә таянган килеш, аллея комында җилфердәп яткан өрәңге яфрагына карап утыра.* А.Тимергалин

4) Йөргәндә, чаңгы шуганда, адымны җиңеләйтү, тизлекне арттыру һ.б.ш. өчен, таяк яки башка махсус әсбап куллану. *Ашыга-ашыга, таякка таянган, пөхтә киенгән бер карчык сәхнә аша чыгып китә.* А.Гадел

5) *күч.* Берәр җирдән ярдәм алу, кемнән дә булса теләктәшлек күрү. *Шул авыр елларда башка чыгып, йорт-җир җиткереп, үз көчләренә таянып яшәделәр.* М.Хуҗин

6) *күч.* Ышану, ярдәм һ.б.ш. өмет итү, көтү. --- *тәҗрибә юлы белән йөрү тиешле, һич беркем көченә вә куәтенә таянмасын һәм имин булмаган кемсәнең алдавыннан курыкмый, хәвефсез тормасын.* Кәлилә вә Димнә. *Күп торганга таянма, күп белгәнгә таян, димәсләр иде.* Ф.Бурнаш

7) *күч.* Берәр факт, тәгълимат нигезендә фикер йөртү, шуларны исәпкә алып эш итү, шуларны дәлил итеп алу. *Мәкаләне укып чыккач, Сәетне, фикер тирәнлегеннән бигрәк, йөзләрчә елларга чигенеш ясап, конкрет фактларга, кире кагып булмаслык дәлилләргә таянып язуы шаккатырды.* М.Хәсәнов. *Иң изге ният, иң якты хыял да, дөнья кануннарына таянмаса, утопия булып кына кала.* М.Галиев

**Таяна башлау** Таянуга күчү. *Моңа кадәр хатыным иркәләнүне һәм үзсүзләнүне гадәте иткән булса, моннан соң һаман да «әйе»гә таяна башлады.* Ф.Яхин

**Таяна бирү** Таянуын дәвам итү. --- *ул күпне күргән, олайган кеше алай кабынып китмәде. Кылычының ялтырап торган җиз башлы сабына таяна биреп, әллә ни булмагандай, тыныч җавап бирде ---.* Г.Бәширов

**Таяна төшү** Бераз таяну.--- *каралтылар, егылмасам ярар дип куркып, үзләренең иске черек тирәкләренә таяна төшеп, һәр җилгә калтыранып, һәр яңгырны эченә алып, язмышның бөтен көчләре алдында ыңгырашып гомер итәләр.* Г.Ибраһимов

**Таянып алу** Беразга гына таяну. *Яңадан аш ашамакчы булса да, утырганда, ялгыш өстәл өстендәге бер звонокка таянып алганлыгыннан, алдындагы аш аска төшеп китеп, аның урынына астан кош жаркое килеп чыкты.* Ф.Әмирхан

**Таянып карау** Сынау максаты белән таяну. *Мин дә бер ирләр көченә таянып карыйм, ничегрәк була икән ул.* З.Мурсиев

**Таянып тору** Таянган хәлдә булу; билгеле вакытка таяну. *Сәүбән дә таянып торган мендәрләрен рәтли башлады.* Г.Гыйльманов. *Фатихны уртага алып, кайсылары чүгәләп кенә утырдылар, кайберләре печән өеме өстенә ятып яки терсәкләре белән таянып тордылар.* Н.Яһудин

**ТАЯНЧЫК** *и.* 1) *этн.* Кызның бирнәсе составында булган терлек; яшь килен мәгәлдәктән төшкән вакытта таяна торган терлек. *Бу төенчектәге көмеш тәңкәләр белән бизәлгән күкрәкчәне ул биемәнә, ап-ак дебет перчатканы таянчык тоткан Барыйга бүләк итте.* Н.Яһудин

2) Култык таягы. *Шуңа төшеп утыра да ике кулындагы таянчыклар белән этенеп выжылдата гына.* Х.Камалов

**ТАЯНЧЫКЛЫ** *и.* Таянчыгы булган (килен тур.)

**ТАЯНЫЧ** *и.* **1.** 1) *сир.* Утырганда, менгәндә яки төшкәндә тотыну, таяну, арка терәү һ.б.ш. өчен терәк; җиһазның таяна торган махсус өлеше. *Урман авызына чыгып җиттем дигәндә, сул аяк каядыр убылып төште, буш кул, таяныч эзләп, нәзек ботакка ябышты ---.* Л.Зөлкарнәй. *Шундый зур, киң яланда, бар дөньяда аңа терәк булырлык, таяныч, дүрт аяктан торып басарлык бер генә таяныч та юк иде.* Д.Булатова

2) Таянган җирлек, таянган урын. *Урыс империясенең, Босфор һәм Дарданелл бугазларын, Истанбул шәһәрен кулга төшереп, Урта диңгезгә чыгуда Болгарияне таяныч итүе --- дә бар ич әле.* Т.Әйди. *Аның хәзер «таянычым – таш, тотканым – тимер» дип яшәрлеге бар иде.* Ф.Яхин

3) *күч.* Ярдәм. *Таяныч эзләп, киңәш сорарга дип килде.* Л.Ихсанова. *Хәзер шул Такылдыктан, үз дошманыннан, таяныч эзли: аны да үз ягына аударырга!* Р.Камал

4) Төп ярдәмче; иң ышанычлы кеше. *Мондый кырыс заманда ялгыз яшәү мөмкин түгел. Миңа таяныч, терәк кирәк. Мин андый кешене таптым, Айрат.* Ф.Яруллин. *Ярмөхәммәт, син бит бөтен таянычым, син – йортның бердәнбер ир-аты...* Р.Батулла

5) *күч.* Рухи яктан ярдәм итә алырлык, нигез булырлык көч; сыенырлык зат яки берәр нәрсә; терәк, ышаныч. *Мисырның Клеопатрасы, --- Византиянең Софьясы шикелле мәмләкәт тоткан югары сәясәтнең үзәгендә кайныйсы, ханның иң якын киңәшчесе, турылыклы көрәштәше, ышанычлы таянычы буласы килә.* М.Әмирханов. *Синең таянычың шул казакларда. Ләкин бу таяныч черек. Вакыт үзгәрүгә, сәясәт какшауга, алар сине ташлап качачак, качсалар гына ярый әле, алар сиңа каршы барачак.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берәр нәрсәнең нигезендә яткан, төп, ышанычлы, иң әһәмиятле. *Туган ягын, аның ямьле табигатен --- ул кешегә рухани өмет, күңел көрлеге, таяныч нокта бирүче көч итеп, --- психологик анализ мөмкинлекләренә ышыкланып сурәтли.* Т.Галиуллин. *Эчендә әйтерсең нидер өзелеп төште, күңеленең таяныч баганалары ауды.* Р.Камал

2) Ярдәм итәрдәй, ярдәм итә торган

**ТАЯНЫЧЛЫ** *с.* 1) Нык, тотрыклы, чыдам. *Монда һәрнәрсә ышанычлы, ныклы, таянычлы.* Л.Ибраһимова

2) Терәге, ярдәм итәрлек кешесе булган. *Таянычлы кеше*

3) *күч.* Ышанырлык, ышаныч багларлык, ышанычлы (кеше тур.). *Кем генә булмасын, кая гына эшләмәсен, инде чәчләре коелгач та, Нәсим белән Рәсимәнең иң турылыклы дусты, таянычлы ярдәмчесе булып калды.* Т.Галиуллин. *Инде янәшәмдә таянычлы кеше бар, дип сөенгән идем.* З.Хәким

4) *күч.* Әһәмиятле, көчле, ышандырырлык. *Әлегә кадәр чыккан татар грамматикаларында бу мәсьәләдә телебезнең табигатенә нигезләнгән, таянычлы гыйльми мәгълүмат юк.* Г.Алпаров. *Миңа да тернәкләнеп гомер итәргә бер таянычлы уй, юаныч кирәк иде ләбаса!* А.Гыйләҗев

**ТАЯНЫЧСЫЗ** *с.* **1.** Таянычы булмаган, таянычтан мәхрүм ителгән, ярдәмгә мохтаҗ. *Без татарлар да таянычсыз халык түгел икәнбез.* Г.Сафиуллина

**2.** *рәв. мәгъ.* Таянычы булмаган хәлдә; таяныч булмый торып, таянычтан башка. *Таянычсыз калган яшь егет укуын өзәргә мәҗбүр була, чөнки инде бу елларда фал ачып җан асрау мөмкин-

*леге тәмам юкка чыга.* Т.Әйди. *Нигезсез, таянычсыз ничек яшәмәк кирәк?!* Г.Гыйльманов

**ТАЯНЫЧСЫЗЛЫК** *и.* 1) Таяныч булмау, терәк, ярдәм җитмәү күренеше; ялгызлык. *– --- безнең яшьтәге кешене үз балалары да, оныклары да бик өнәп бетерми, картлар аларга комачаулаган кебек тоела бит. – Алай ук булмаса да, барыбер канатсызлык, таянычсызлык сиздерә, Зөлфә.* З.Фәйзи

2) Өметсезлек, чарасызлык. *Гаязның йөзенә чыккан өметсезлек, таянычсызлыкка карап елыйсым килә иде минем.* М.Әмир

**ТАЯ́У** I *ф.* Берәр нәрсәне тотрыклырак итү өчен, янына өстәмә терәк кую, терәү. *Багана белән таяу*

**Таяп кую** Таяу хәстәрен күрү; алдан ук таяу

**Таяп тору** Гел, һәрвакыт таяу; таяу процессында булу

**Тайый төшү** Бераз гына таяу

**ТАЯ́У** II *и.* 1) Терәк, берәр нәрсәне тотрыклырак иткән терәү. *Шул ук иске болдыр, борынгы таяу-колонналар.* Р.Камал

2) *күч.* Таяныч була алырлык кеше, ярдәмче. *Ир бала – ата-анага таяу.* Мәкаль

3) *күч.* Берәр күренешнең нигезе, терәге булган нәрсә, аның әһәмиятле өлеше. *Ул төзегән дәүләт җимерелә, таяу баганалары ава.* Р.Камал

**ТАЯУЛЫ** *с. сир.* 1) Терәтелгән, терәүле. *Таяулы капка*

2) Баганаларга, субайларга утыртылган, терәкле. *Эреле-ваклы күперләр, таяулы һәм асмалы басмалар күп ул авылда, ә Олы күпер берәү генә, аннан ат белән дә, машина белән дә үтеп була.* Г.Якупова

**ТӘ** *кис. к.* **да** I. *Бер генә көпчәк тә юлда син югыннан туктамас.* Н.Исәнбәт. *Килеп кергәч тә сәлам бирү*

**ТӘӘССЕФ** *и. гар. иск.* **1.** Кайгы, үкенеч, ниндидер эшнең уңмавына ачыну тойгысы. *Матбугатта тәәссеф изһар итүчеләр йөзләп саналгач, тәәссефләрен эчләренә йотып калучылар әлбәттә меңләп саналырга тиеш.* Г.Рәхим. *Мең тәәссеф тә аз күренәдер Милли көйгә шигырь язганга ---.* Ф.Хәйбуллин

**2.** *с.* Үкенечле, кайгылы, борчулы, ямьсез, күңелсез. *«Русское общество»-ның бундый эшләргә бер дә дикъкать итмәве тәәссеф бер хәлдер.* Г.Камал. *Мулла булгач та, озакламый кеше гаепләрен эзләргә керешеп, Кышкарый, Мәрҗани, Барудиларның әсәрләренә рәддияләр язып, вакытын әрәм итеп, тәәссеф хәлләргә сәбәп булды.* Р.Зарипов

**3.** *кер. сүз функ.* Кызганычка, ни кызганыч, ни үкенеч. *Очтылар хәзрәт, вәкил – күп очтылар, Тик, тәәссеф, җиргә егылып төштеләр.* Г.Тукай. *Ләкин шулкадәресе бар: тәәссеф ки, без боларның эчендә ни үземезнең «татар шагыйре» дип әйтерлек бер затны, ни халкымызның рух вә хиссиятене күрмибез яки бик аз күрәбез.* Җ.Вәлиди

**ТӘӘССЕ́Ф ИТҮ** *ф. иск.* Үкенү, кызгану хисләре кичерү. *Ул бит, сеңелкәш, безнең ише аристократлар, чак кына тегеләй-болай берәр нәрсә булдымы, – бик рәхмәт, тәәссеф итәм, тәшәккердән гаҗиз, илтифатыгызга мәгалмәмнүн, гафу итә күрегез, әфәндем...* Ш.Камал. *Бу үзенчә бик тәрбияле рәвеш белән --- сүз башлады: – Әфәнделәрем, – диде. – Мин яшьләремезнең бер хәленә һәм тәгаҗҗеп, һәм тәәссеф итәм.* Г.Ибраһимов

**ТӘӘССЕ́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәәссеф итү**. *Кайчан ки Әхмәд әл-Җәвад тәәссеф кыйлып еглады, карчыга вә күгәрчен тавыш бирделәр.* К.Насыйри

◊ **Тәәссефкә каршы** *к.* **кызганычка каршы**. *Бу эштә, тәәссефкә каршы, икенче тәфсиргә генә муаффәкыять итәргә тугры килә, чөнки аның юашлыгы хакында сөйләшергә мөмкин түгел.* Г.Исхакый. *Ләкин, тәәссефкә каршы, бу нәрсә булып бетә алмый.* Сәхнә

**ТӘӘССЕФЛЕ** *с. кит.* 1) Көенечле, кызганыч, үкенечле хисләр тудыра торган. *Бинаән галәйһи бу кеби хата вә тәәссефле хәл булмаганына һәм мөселман булуым, һәм русияле бер гражданин булуым җәһәтеннән шатланам.* С.Максуди. *Иң тәәссефлесе: милләтнең, баш иеп, кяфергә кол булуыдыр.* А.Тимергалин

2) Берәр нәрсәне кызгану, берәр нәрсәгә кайгыру, үкенү кебекләрне белдерә торган. *Тәәссефле караш*

**ТӘБАРӘК** *и. гар. дини* Коръәндә Аллаһны мактауга багышланган сүрә, «Мүлк» сүрәсе. *Күмү эше тәмам булды. Хәзрәт бик моңлы иттереп «Тәбарәк» сүрәсен укыды.* М.Гафури. *Алар каберлек капкасыннан чыккан вакытта, мәзин, нечкә сакалын селкетеп-селкетеп, кабер янында «Тәбарәк» укый иде.* Ш.Камал

◊ **Тәбарәген укыту** *ирон.* Ни белән дә булса кешене үлем хәленә җиткерү; үтергәнче кыйнау (гадәт буенча үлек өстендә «Тәбарәк» сүрәсен укудан әйтелә). *[Сәйфулла:] Әх, Хәйрүш, авылга да җитәбез диген, ә... Ну, Хәйрүш, кайтып, байларга тәбарәкләрен укытабыз.* Ф.Бурнаш

**ТӘБӘ** *и.* 1) Майга яки сөткә туглап, табада куырылган йомырка. *Кечкенә генә тимер мич өстендә майда кыздырылган тәбә өлгергәч, Гыйльфан бөтенләй кәефләнде.* Ш.Усманов. *Сөт, тоз, борычны йомырканы туглагач кына өстәсәң, тәбә тәмлерәк була.* Татар халык ашлары

2) *диал.* Тары оныннан пешерелгән белен

◊ **Тәбәңне чәчермен** Бик каты тиргәү, шелтәләү яки тәнкыйтьләү сүзе

**ТӘБӘГА** *и. гар. иск.* Билгеле бер монархка сәяси-хокукый бәйлелектә булган физик затлар; подданныйлар. *Алтын Урданың тәбәгасе, ягъни подданныйлары булган рус кенәзләре, хан белән көрәшер өчен, Сарайга килергә тиеш булдылар.* С.Алишев. *Бөтен Русиядә иң юаш һәм итагатьле тәбәга саналган татарларга Төркестанда җирләшергә рөхсәт бирмиләр.* Гасырлар авазы

**ТӘБӘЛДЕРЕК** *и.* 1) Туку станында аяк белән басып көреләрне хәрәкәткә китерә торган кечкенә такта. *Тәбәлдерек ачкан җеп карнында Чабак – соса уйнап югала. Һәм көреләр парлап биеп тора, «Һап та һоп!» дип кылыч кул чаба.* Ш.Маннур. *Шүрегә җеп урый, шүрене сосага кертә дә, сосаны бик оста гына шудырып, аркылы җепне икенче яктан тартып ала да, аягы белән тәбәлдерекне төшереп, палас кылычы белән аркылы җепкә суга.* Р.Батулла

2) Төрле машиналарда һәм уен коралларында аяк белән басып механизмны

хәрәкәткә китерә торган җайланма; педаль. *Ярмөхәммәт, тиз генә машинасының муфта тәбәлдерегенә басып, кул тормозын ычкындырды.* Р.Батулла. *Тәбәлдереккә басым артса, калыпларның да барабаннарга басымы арта.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ТӘБӘЛДЕРЕКЛЕ** *с.* 1) Тәбәлдерегe булган. *Бу инде сиңа теге тәбәлдерекле насос кына түгел, суны авылның бер ягыннан икенче ягына ук аттыра.* Г.Рәхим

2) *диал.* Мәшәкатьле, расходлы. *Туй ул бик тәбәлдерекле була*

**ТӘБӘНӘГӘЮ** *ф. к.* **тәбәнәкләнү**

**Тәбәнәгәеп калу** Берәр сәбәпле тәбәнәк хәлгә килү. *Ләкин Галия тавы аларга инде ничектер сулыгып, тәбәнәгәебрәк калган шикелле күренә.* Т.Мөбарәков. *Хәзер әнә балбал бер башка тәбәнәгәеп калган.* М.Галиев

**Тәбәнәгәя бару** Акрынлап тәбәнәгәю. *Таулар елдан-ел тәбәнәгәя баралар*

**Тәбәнәгәя төшү** Бераз тәбәнәгәю; тагын да тәбәнәгәю

**ТӘБӘНӘК** *с.* 1) Биек булмаган, биек түгел (каралты-кура, төрле корылмалар тур.). *Ике якта кар белән яртылаш күмелгән басык вә тәбәнәк өйләрнең кечкенә вә ямьсез тәрәзәләреннән саргылт шәүләләр сузылып киткән иде.* Ш.Камал. *[Фабриканың] Корпус эче буш булып, зур бер йорт шикелле киң, тәбәнәк булганлыктан, тәрәзәләрдән кергән көн яктылыгы уртасына ук барып җитә алмый.* Ш.Усманов

2) Җиргә, нигезгә яки берәр өслеккә якын урнашкан, түбән. *Инешнең бер ягы тәбәнәк, икенче ягы биегрәк.* Г.Коләхмәтов. *Идел үзе, зәңгәрлеккә өртелә барган аргы яктан алып бирге якның тәбәнәк ярына кадәр, --- һаман ага.* Г.Бәширов

3) Кыска буйлы, гадәттә юантык, базык (кеше һәм хайваннар тур.). *[Мәйданга] тәбәнәк кенә юан бер егетне чыгардылар.* М.Гали. *Юан гына, тәбәнәгрәк кенә бу кеше Вилданнан аеруча күзен алмый.* Г.Толымбай

4) Кыска, озын булмаган. *Тукайның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле --- ботинка иде.* М.Гали

**ТӘБӘНӘКЛӘНҮ** *ф.* Тәбәнәк хәлгә килү. *Бикташның үзенә дә посёлок үзгәргән: йортлар тәбәнәкләнгән, тыкрык тарайган, Васька кечерәйгән төсле күренде.* М.Маликова. *Тау куышы шулкадәр тәбәнәкләнде, егет чүгәләп бара башлады.* М.Җһудин

**Тәбәнәкләнә бару** Торган саен тәбәнәкләнү. *Нужа баскан саен тәбәнәкләнә барган гәүдәле Мостафа аңа борчылмаска кушты.* К.Нәҗми

**Тәбәнәкләнә башлау** Тәбәнәкләнүгә табан бару. *Алардан соң инде таулар тәбәнәкләнә башлады, гүя алар да, адәм баласының бернигә карамастан ярсып алга атлавына тетрәнеп, аның алдында тез чүккәннәр иде.* Ф.Бәйрәмова

**Тәбәнәкләнә төшү** Бераз тәбәнәкләнү; тагын да тәбәнәкләнү. *Бәлки, бөек Атилланың сөякләре Венгрия далаларында заманнар үтү белән шактый тәбәнәкләнә төшкән берәр курган эчендә ятадыр.* Борынгы төрки халыклар тарихыннан хикәяләр

**Тәбәнәкләнеп бетү** Бөтенләй тәбәнәкләнү

**Тәбәнәкләнеп калу** Берәр тәэсирдән, вакыйгадан соң тәбәнәк хәлгә килү. *Өйләр генә бераз тәбәнәкләнеп калганнар, искергәннәр иде бугай.* Н.Фәттах. *Болай да бодай көлтәсе чаклы гына карчык тагын да бөрешә, тәбәнәкләнеп калды.* Р.Батулла

**Тәбәнәкләнеп китү** Сизелерлек дәрәҗәдә, күзгә күренеп тәбәнәкләнү. *Кечкенә буе тагын да тәбәнәкләнеп китте.* Ф.Яруллин. *Ә тауны инде әйткән дә юк, ул хәзер генә тәбәнәкләнеп киткән кебек, әлек ул бәләкәй Камил өчен дөньяның иң биек тавы булып тоела иде.* Ф.Бәйрәмова

**ТӘБӘНӘКЛЕК** *и.* Тәбәнәк булу. *Аксак аяк һәм буй тәбәнәклеге комачау итсә итәр. Әмма дә хатыны чибәр һәм калку булыр.* Р.Яхин

**ТӘБӘНЧӘ** *с. диал.* Кыска буйлы, карсак. *Тәбәнчә хуҗабикә*

**ТӘБӘР** *и. лат. бот.* Әспечәләр семьялыгыннан хуш исле ак чәчәкләре тәлгәшләнеп тора торган декоратив үлән үсемлек (парфюмериядә эфир мае алу өчен кулланыла); тубероза

**ТӘБӘССЕМ** *и. гар. иск.* Елмаю, көлемсерәү. *Булмадың алтын ярым – салкын ярым, син дә минем Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы.* Г.Тукай. *Ул синең иркеңне уйнаткан тәбәссемне ала, күзләреңнән нурлы шатлыкны җыеп, хәсрәт сала.* Ш.Бабич

**ТӘБӘССЕ́М ИТҮ** *ф. иск.* Елмаю, көлемсерәү, көләч йөз күрсәтү. *Гөлсәрах тәбәссем итеп җавап бирде: «Җәмигъ былбыллар миңа гашыйк булып, йокыларыны, ашау-эчүләрене оныттылар».* Ф.Халиди. *Сөйгәнем итсә тәбәссем, сөенечемнән җан эри.* Х.Сөнгатьзадә

**ТӘБӘССЕ́М КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәбәссем итү**. *Әмма Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре захик түгел, тәбәссем дә кыйлмады.* К.Насыйри

**ТӘБӘШӘК** *с. диал. к.* **тәбәнәк.** *Мөхәммәдәмин ятагына терәтеп куелган тәбәшәк өстәлгә кагылгандай итте.* М.Әмирханов. *Менә әле дә тәбәшәк өенең түрендәге сәкегә утырып, шул вакыйгаларны искә төшереп утырды.* А.Хәйртдинова

**ТӘБӘШӘКЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **тәбәнәкләнү**. *Башкала халкы күп кенә учреждениеләргә илтүче юлларда бордюрларның тәбәшәкләнүен --- күрмичә калмагандыр.* Кызыл таң

**Тәбәшәкләнә бару** Акрынлап тәбәшәкләнү

**Тәбәшәкләнә төшү** Бераз тәбәшәкләнү; тагын да тәбәшәкләнү. *Карт бераз тәбәшәкләнә төшкән*

**Тәбәшәкләнеп бетү** Бөтенләй тәбәшәкләнү

**Тәбәшәкләнеп калу** Берәр вакыйгадан, тәэсирдән соң тәбәшәкләнгән хәлгә килү. *Вак яңгыр сибәләргә тотынды, күк йөзе томаланып, тәбәшәкләнеп калды.* Ә.Маликов

**Тәбәшәкләнеп килү** Аз-азлап тәбәшәкләнү

**Тәбәшәкләнеп тору** Тәбәшәк булу; тәбәшәк булып күренү. *Кара аны, мылтыкны капканың сул ягына, читән тәбәшәкләнеп торган урынга сөя, дип тәфсилләп аңлатты Гыймазетдин.* Казан утлары

**ТӘБӘШӘКЛЕК** *и. диал. к.* **тәбәнәклек**

**ТӘБГЫ** *и. гар.* Күп мәртәбә чыгарыла торган әсәр, китап һ.б.ш.ның чираттагы басмасы. *Бу тәбгысында да хикәяне бик аз төзәттем.* Ф.Әмирхан. *«Татар тарихы»ның 21 нче тәбгысы*

**ТӘБЕ** *и.* 1) Тычкан, күсе кебек вак җәнлекләрне тоту өчен ясалган кечкенә капкын; тозак. *Ул әрле-бирле йөренде, карават астыннан тычкан тәбесе тартып чыгарды.* А.Гыйләҗев. *Ни гаҗәп, бушлай сырның тәбедә генә булуын халык әле һаман да аңлап җиткерә алмый.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Котылу чарасы, чыгу юлы булмаган берәр бәла, авыр хәл; тозак

**ТӘБЕРСЕН** *и. этн.* Керәшеннәрнең мәҗүсилектән үк калган үлгән кешеләрне искә алып аш уздыру йоласы

**ТӘБЕРСЕ́Н ИТҮ** *ф.* Аштан авыз итү. *Һәрбер үлемне искә алу көнендә коймак белән тәберсен иткәннәр, мал суйганнар.* М.Глухов. *Кияү белән килен, туган-тумачалар ризалыгын алганнан соң, ипи-тоз кабып тәберсен итәләр.* Казан утлары

**ТӘБИКМӘК** *и. к.* **табикмәк**. *Кулдан суккан чуар ашъяулык җәйгән сәкедәге табында итле өйрә, ботка, кәрәзле бал, бер коштабак тәбикмәк куелган иде.* А.Тимергалин

**ТӘБИЯ** *и. фар. диал.* 1) Бодай кабартмасы. *Без кайтышка әнкәй тәбияләр пешереп көтеп торган*

2) Тәбә. *Тәбия пешерү*

◊ **Тәбия тансыгы** 1) Кадерле, иркә бала; 2) Ризык пешүгә генә килеп керүчән, бик үк көтелмәгән әрсез кунак; 3) Кирәксез, файдасыз кеше турында

**ТӘБЛИГЪ** *и. гар. кит.* Ирештерү, тапшыру, белдерү, хәбәр итү. *Ислам динендә тәблигъ хезмәте белән шөгыльләнүчеләрнең иң әүвәлгесе Рәсүлулла булса, фәтва бирүчеләрнең дә әүвәле улдыр.* Р.Фәхретдин

**ТӘБЛИ́ГЪ ИТҮ** *ф. кит.* Ирештерү, тапшыру, белдерү, хәбәр итү. *Рәсүлулла хәзрәтләре бөтен дөнья халкына җибәрелгән булу сәбәпле, ислам динен тәблигъ итү (тарату, ирештерү) фарыз булуы, Коръән Кәримне төрле телләргә тәрҗемә итү лазем икәнлеге аңлашыла.* А.Тимергалин

**ТӘБРИК** *и. гар.* Берәр бәйрәм, шатлыклы вакыйга уңае белән язмача яки телдән котлау, бәрәкәт теләү. *Аннары үз палатабызга кайтып, иптәшләрнең тәбрикләрен профессорга тапшырдым.* Г.Әпсәләмов. *Ахырдан ул, шактый ватып-җимереп, русча да бер-ике тәбрик сүзе әйтте.* М.Мәһдиев

**ТӘБРИ́К ИТҮ** *ф. к.* **тәбрикләү**. *Сез дусларны тәбрик итәм Бүгенге шатлык белән!* Җыр. *Ә артист, ике кулын кушып, яткан җиреннән селкә-селкә: – Андрюша, җир! Тәбрик итәм! – дип кычкырды.* Г.Әпсәләмов

**ТӘБРИ́К КЫЛУ** *ф. к.* **тәбрикләү**. *Бу эшеңез өчен тәбрик кыла алмыйм...* Г.Исхакый

**ТӘБРИКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр төрле шатлык яки бәйрәм уңае белән котлау. *Кунак Яңа ел белән тәбрикләп вакыт уздырып торуны кирәк тапмады.* Т.Галиуллин. *Председатель халыкны тәбрикләргә тиеш иде. Ләкин: «Иптәшләр», – дип кенә калды.* Казан утлары

2) Кемнең дә булса эше, хезмәте турында уңай фикердә булу, хуплау, теләктәшлек белдерү. *Гомуми шатлык авазы көчәя. Яшьләр күбрәк шагыйрьне тәбрикли, үзенең мәхәббәтен, ихтирамын әйтеп калырга ашыга.* Т.Галиуллин

**Тәбрикләп йөрү** Төрле җирдә, төрле вакытта тәбрикләү. *Татар почмагында милли коллективларны бәйрәм белән тәбрикләп йөргән шәһәр башлыгы Виктор Шрейдер, хакимият вәкилләре һәм кайбер депутатлар булды.* С.Мирхалиева

**Тәбрикләп кую** Алдан ук тәбрикләү. *Бу хакта Табиев алдан ук әйтеп һәм тәбрикләп куйган иде.* Г.Бәширов

**Тәбрикләп тору** Гел, һәрвакыт тәбрикләү; хәзерге моментта тәбрикләү. *Хәния апасы Казанда, телефоннан гел хәлемне сорашып, бәйрәмнәр белән тәбрикләп тора.* Татар әдипләре

**Тәбрикләп чыгу** Барысын да, һәрберсен тәбрикләү. *Андрей Николаевич шулай ук хастаханәдә ятып дәваланучы православныйларны, полициядә вакытлыча тоткарланучыларны Пасха белән тәбрикләп чыкты.* Әлки хәбәрләре

**Тәбрикли башлау** Тәбрикләргә керешү. *Килеп җитүгә, кулымны кыса, тәбрикли башлады.* Безнең гәҗит

**ТӘБРИКНАМӘ** *и. гар.-фар.* Язма тәбрик, тәбрик хаты. *Китап чыкканнан соң бер ай ярым эчендә утыз дүрт тәбрикнамә алган идем.* С.Максуди

**ТӘВАФ** *и. гар.* 1) *дини* Ислам динендә хаҗ вакытында Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнеп чыгу. *Һәм безне иртән иртүк тәваф гамәлен үтәү өчен уяттылар.* Кызыл таң. *Кәгъбәне җиде кат әйләнгәч, шул ук урында тәваф тәмамлана һәм тәваф намазы укыла.* Кәеф ничек?

2) *иск.* Берәр кеше яки берәр нәрсә тирәсендә әйләнү, йөреп чыгу

**ТӘВА́Ф ИТҮ** *ф.* 1) *дини* Ислам динендә хаҗ һәм гомрә вакытында Кәгъбә тирәли әйләнеп йөрү. *Госелсез кешегә намаз уку, Коръән уку, Коръәнне кулга тоту, Кәгъбәне тәваф итү, берәр мәҗбүрият булмаганда, мәчеткә керү тыела – харам.* Ватаным Татарстан

2) *иск.* Берәр кеше яки предмет тирәсендә әйләнеп чыгу. *Туташ [егет] әйләнәсендә тыраклап тәваф итеп карады.* Ф.Әмирхан

**ТӘВА́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **тәваф итү**. *Хаҗилар Кара ташны үбәргә хыяллана. Тәваф кылганда, кайвакыт кул сузымы кадәр генә ара кала.* Безнең гәҗит

**ТӘВӘ** *и. к.* **дөя**. *[Чалдаев:] Үз эшемне намус белән башкарам, буй җитмәс җирләргә үрелмим, чөнки тәвәдән биек фил бар икәнен беләм.* Г.Әпсәләмов. *Шулай да бозлавык булыша: озын аяклы тәвә асфальтта таеп егыла.* Татарстан яшьләре

◊ **Тәвәне төге белән йотар** Гаять дәрәҗәдә ашамчак кеше турында

**ТӘВӘККӘЛ** *с.* **1.** 1) Берәр эшкә керешкәндә яки карар кабул иткәндә куркып тормый торган, йөрәкле, кыю. *Үз араларыннан шундый бер тәвәккәл йөрәкнең килеп чыгуын гына көткән Тигәнәле кешеләре аяк терәп җир сорыйлар.* К.Нәҗми. *Әниебез бик тәвәккәл кеше иде, олы абыебыз Мәгъфүргә ат җигеп кайтырга кушты.* М.Мәһдиев

2) Зур кыюлык, ныклык, үз-үзеңә ышанганлык, икеләнмәүчелек таләп итә торган. *Бу төндә эшләнергә тиешле*

*тәвәккәл һәм җаваплы эш өчен Зарифулла хәтсез кулай кеше инде.* Г.Минский. *– Хәзер, Нургаяз ага, чәй эчеп җибәрәбез, – диде егет, үзенең тәвәккәл хәрәкәтләре белән өйгә җан кертергә омтылгандай.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *и. мәгъ.* Үз-үзенә нык ышана, икеләнми торган кыю кеше. *Тәвәккәлдә тау көче.* Мәкаль. *Уйлы уйлап торганчы, тәвәккәл эшен бетерер.* Мәкаль. *Тәвәккәлгә тугыз җирдән Хак Тәгалә бирәм дигән.* Г.Афзал

**ТӘВӘККӘ́Л БҮРЕК** *и. этн.* Мех эчле, тышы хәтфә яки постаудан 15–20 см биеклегендә итеп тегелгән, гөмбәз сыман түбәле, колакчынсыз баш киеме. *Иртәнге салкыннарда киеп йөрерсең дип, әни әтинең тәвәккәл бүреген һәм, җиңнәрен бераз кыскартып, аның кылкаланып беткән тула чикмәнен бирде.* М.Гали. *Мин, туганкай, тәвәккәл бүрекне кырын киеп алып, шул Шәрифәгә өйләнергә булып торам инде.* Н.Исәнбәт

**ТӘВӘККӘ́Л ИТҮ** *ф. иск. к.* **тәвәккәлләү**. *Тәвәккәл иткәндә ул да үз дигәненә ирешә ала икән болай булгач...* Р.Мөхәммәдиев

**ТӘВӘККӘ́Л КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәвәккәләү**. *Тәвәккәл кыл, иҗтиһат ит, эшкә кереш!* М.Гафури

**ТӘВӘККӘЛЛӘҮ** *ф.* Берәр эшкә керешергә батырчылык итү, икеләнмичә, ачык берәр карар кабул итү. *Эшне башлаганчы тәвәккәллә.* Мәкаль. *[Саҗидә:] Гариф абый, киңәшеп тотсак, начар килеп чыгар, дисезмени?.. Әйдәгез, тәвәккәллик, җәмәгать!* М.Галәү. *Апа урынга яткач, күнозын алмагачлардан күзен алмады. Шундый кызгандым, ни куркыныч булса да тәвәккәлләдем.* Г.Гобәй

**Тәвәккәлләп карау** Нәтиҗәсен белер өчен тәвәккәлләү. *Нишлисең, башка юл юк: тәвәккәлләп карарга кирәк, тәвәккәлләр генә таш яра.* К.Кара

**Тәвәккәлли башлау** Тәвәккәлләргә тотыну. *Әсрардан үрнәк алып, аның эзе буенча башка сугышчылар да тәвәккәлли башладылар.* Г.Әпсәләмов

**Тәвәккәлли төшү** Тагын да бераз тәвәккәлләү. *Хәтта мин, тәвәккәлли төшеп, болай дип тә әйтә алыр идем: поэзия билгеле дәрәҗәдә үзенең башлангычын югалтудан ала.* Ф.Хөсни

**ТӘВӘККӘЛЛЕК** *и.* Берәр эшкә керешүдә, билгеле бер карарны икеләнүсез кабул итүдә кыюлык, батырчылык. *Нишлим соң? Биергә һәм биек тау башыннан чаңгыда төшәргә гомер буе тәвәккәллек җитмәде.* М.Мәһдиев. *Ә бит кыюлык һәм тәвәккәллек белән эш иткәндә җиңәргә була иде әле.* И.Хуҗин

**ТӘВӘККӘЛЛЕ́К ИТҮ** *ф. к.* **тәвәккәлләү**

**ТӘВӘККӘЛЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **тәвәккәлләү**. *Минем юлдашым Валентин Васильевич, үзләшә төшеп, сөйләшүне конкретлаштырырга тәвәккәллек кылды: – Әйт әле, Сергей, син менә үзең кайсы якныкы? – диде ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Әгәр Пхеньян бу юлы бернигә карамый атом-төш сынауларына тәвәккәллек кылса, Берләшкән милләтләр оешмасының (БМО) аны кискен тәнкыйтьләп чыгачагы яхшы аңлашыла.* Өмет

**ТӘВӘККӘЛСЕЗ** *с.* Бер фикергә килә алмый торган, карар кабул итүдә кыюсыз. *Тәвәккәл таш йотар, тәвәккәлсез бармагын тешләр.* Мәкаль

**ТӘВӘККӘЛСЕЗЛЕК** *и.* Тәвәккәлсез булу үзенчәлеге

**ТӘВӘККӘЛЧЕ** *и. сир.* Тәвәккәл кеше. *Уйчы уйлый торыр, тәвәккәлче Уел кичәр.* Мәкаль

**ТӘВӘККҮЛ** *и. гар.* Аллага тапшыру, Алла ярдәменә сыену хәле. *Мин күчтем, юлландым, дидем: Аллага тәвәккүл.* Дәрдемәнд. *Бу адәмнәрне Габбас яманласа да, Сәлим мулла бик мактап: «Суфи вә тәкъва адәмнәр, Ходага тәвәккүлләре там», – дип әйтә иде.* З.Һади

**ТӘВӘККҮ́Л КЫЛУ** *ф.* Аллага тапшыру, Аллага ышанып, язмышка риза булу. *Тик сабыр ит тә тәвәккүл кыйл Хода хәзрәтенә.* Н.Думави

**ТӘВӘ́ КОШЫ** *и. зоол.* Тәвә кошлар семьялыгының бердәнбер вәкиле булган, Африканың чүл һәм ярымчүл зоналарында тереклек итә, оча алмый, ләкин бик тиз йөгерә торган, дөньядагы иң эре кошларның берсе; *русчасы:* **страус**. *Тәвә кошлары төркемләшеп саванналарда тереклек итәләр.* Зоология. *Картиналарны карап йөргәндә, игътибарымны тәвә кошы рәсеме җәлеп итте.* Ватаным Татарстан

**ТӘВӘЧЕ** *и.* Тәвә асраучы; дөя белән йөк ташучы кеше. *Тәвәче белән күрше булсаң, капкаң биек булсын.* Мәкаль. *Зинданга барыңыз, анда Мансур исемле тәвәче бардыр, хозурыма китереңез!* К.Насыйри

**ТӘГА́ЕН** *рәв.* **1.** 1) Төгәл итеп, анык, конкрет рәвештә (берәр нәрсәне белү, әйтү һ.б.ш. тур.). *Туксанынчы еллар ахырында, яңа гасыр башында үзәктән иңгән сәясәтнең мәгънәсен, асылын ул [А.Гыйләҗев] тәгаен ачып бирде.* Т.Галиуллин. *Ул [Г.Ахунов] обком, кабмин ишекләренең кайсы якка ачылганын тәгаен белеп яшәде.* Казан утлары

2) Тулы ышаныч белән, һич шикләнмичә (эш-хәрәкәтнең үтәләчәге яки үтәлгәнлеге тур.). *Әминә бу сүзләргә әллә ничек уңайсызланып, --- теләртеләмәс кенә җавап бирә иде: – Тәгаен белмим. Яхшы, савыга бугай иде.* Ф.Әмирхан. *Басуда күзгә яңгырга калган күлләвләр булса, болар Йосыфныкы, дип тәгаен әйтергә мөмкин иде.* М.Галәү

**2.** *с. мәгъ.* 1) Анык, ачык, төгәл. *Һәр чорда үзгәрә торган, татарча тәгаен тәрҗемәсе табылмаган «конъюктура» аларны [язучыларның әсәрләрен] да читләтеп үтмәде.* Казан утлары

2) Санаулы. *Ләкин тәгаен көннәр дә узып китте.* Ә.Фәйзи

3) Билгеләнгән, инде ачыкланган, конкрет, төгәл билгеле булган. *Эшнең тәгаен срогын әйтү*

4) Ныклы, ышанычлы, төпле. *Әтисенең тәгаен бер кәсебе булмый: җәйләрен --- көнлекче булып эшләп йөри, кышларын ит сатып көн кичерә.* Ә.Еники. *Югары партия мәктәпләре гомуми белем биреп, шәкертләренә диплом тоттырып чыгарсалар да, тәгаен бер һөнәргә өйрәтмиләр иде.* Т.Галиуллин

**3.** *и. мәгъ.* Төгәллек, аныклык, ачыклык. *Иртәгә Сәгыйтьдин абыйдан барып сорыйк, ул безгә тәгаенен генә әйтеп бирер.* Ф.Хөсни

**4.** *кер. сүз. функ.* Әлбәттә, һичшиксез. *Тәгаен, сез бу турыда берни белмисез*

**ТӘГА́ЕН ӘЙЛӘҮ** *ф. к.* **тәгаен итү**. *Көтүче Тимербайны куйлар көтәргә,*

*Миңлешаһ илә Сәфәргалине сукага тәгаен әйләделәр...* З.Һади

**ТӘГАЕ́Н ИТҮ** *ф. иск. кит. к.* **тәгаенләү**. *Бу бүлмә Миңлесылуның үзенә тәгаен ителгән бүлмә иде.* Ф.Әмирхан. *Менә җитте минут: шул усал адәм, тегендә утырган тугыз кешегә карап, ике-өч хәрефлек бер генә сүз әйтә, һәм шул синең язмышыңны тәгаен итә.* Г.Ибраһимов

**ТӘГАЕ́Н КЫЛУ** *ф. к.* **тәгаен итү**

**ТӘГАЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тәгаенләү**. *Шул киңәшмәдә восстание вакытында кем ни эшләргә тиешлеге тәгаенләнеп, һәркемгә конкрет бурыч билгеләнә.* Р.Мостафин. *Өчиле мулласы Зиннәтулла имамның өлкән кызы Бибимәмдүдәнең дә тормышы шушы йомык түгәрәк эчендә тәгаенләнде. Тәгаенләнде, ләкин түгәрәк эченә сыймады.* Казан утлары

2) Берәр хәл, мәсьәлә ачыклану, билгеле ачыклык керү, төгәллек барлыкка килү

**Тәгаенләнә башлау** Тәгаенлек барлыкка килү. *Бу тенденция инде тәгаенләнә башлады*

**Тәгаенләнә төшү** Тагын да ачыграк тәгаенләнү. *Бер шигырьдә ачык итеп әйтеп бетерелмәгән уй икенчесендә тәгаенләнә төшә.* Р.Рахман

**Тәгаенләнеп бетү** Тулысынча тәгаенләнү. --- *өйләнү, солдаттан никахлы хатын белән кайтып төшү егетнең башында тәмам укмашып, тәгаенләнеп беткән фикер түгел иде.* Т.Галиуллин. *Әле федераль казнадан киләсе акчалар да тәгаенләнеп бетмәгән, димәк, проектка төзәтмәләр кирәчәк.* Ватаным Татарстан

**Тәгаенләнеп җитү** Тиешле, кирәкле, көтелгән дәрәҗәдә тәгаенләнү. --- *империя башында тәүгечә мәҗүси римлылар утыралар, гәрчә алар арасында төрле диннәргә йөз тоту шәйләнеп килсә дә, дәүләтнең төп дине тәгаенләнеп җитмәгән иде әле.* М.Хәбибуллин. *«Инновация», «модернизация» дигән сүзләрне мул куллансак та, заманча яшәү юллары-ысуллары әле тәгаенләнеп җитмәгән кебек.* Ватаным Татарстан

**Тәгаенләнеп килү** Тәгаенләнү алдында булу. *[Я.Емельянов] Иҗаты турында үз фикерем үзгәрә-үзгәрә байтак еллардан бирле тәгаенләнеп килә инде.* Р.Фәйзуллин

**ТӘГАЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Ачыклау, төгәл белү; аңлау, төшенү. *Илдус аның кем булуын, нинди профессия кешесе икәнен дә тәгаенли алмады.* Г.Мөхәммәтшин. *Тәүге салышта ук йөзек Бибимәмдүдә учына ояланды. Алдан сөйләшеп-килешеп куйганнар иде ахры, аның кем кулында икәнен дә бик тиз тәгаенләделәр.* Казан утлары

2) Билгеле бер эшкә, вазифага, урынга билгеләү, тәгаен итү. *Чабарга тәгаенләгәч, ул каравылчыдан чалгы сорап алды.* С.Шәмси. *Аны институттан Казандагы автотранспорт берләшмәсе карамагына эшкә тәгаенләп җибәрделәр.* В.Нуруллин

3) Гомумән берәр нәрсәнең вакытын, урынын, күләмен һ.б.ш.ларны билгеләү, атап кую. *Биреләсе урынны Ибрай тыкрыгыннан тәгаенләгәннәр икән.* Г.Әдһәм. *Барлык укучыларга, укытучыларга берничә ай алдан хатлар язганнар, очрашу көнен тәгаенләгәннән соң, чакыру җибәргәннәр.* И.Нәбиуллина

4) Исәпләү, кемне яки нәрсәне күздә тоту, шуңа атау. *Рөстәм һәрвакыт аңа тәгаенләп берәр яңа кыз алып килә, таныштыра, күз дә кысарга өлгерә.* Д.Булатова. *Матильдага тәгаенләп берәр кызылны алырга булды.* К.Кара

**Тәгаенләп калу** Вакытында тәгаенләү

**Тәгаенләп китү** Башка сүз яки эш уңаеннан гына тәгаенләү. *– Синең атаң, минем исә падишаһым Василий Иванович, – дип, алдан әзерләп куйган күп сүзле мөрәҗәгатен тәгаенләп китте* ---. М.Әмирханов

**Тәгаенләп кую** Алдан тәгаенләү; тиз арада тәгаенләү. *Әгәр районда риза булып тәгаенләп куйсалар, Абызтамакка күченергә туры килер.* З.Мурсиев

**Тәгаенләп тору** Вакытлыча тәгаенләү; тәгаенләргә уйлау. --- *хансыз ханлык булмый, без кабат Шәехгали ханны тәгаенләп торабыз, туганым Гәүһәршад тәнәкә дә ризалашырдыр, дип ышанам.* М.Әмирханов. *Әйе, Локман абый аны савыт-саба кибетенә тәгаенләп тора.* Г.Галиева

**Тәгаенли башлау** Тәгаенләргә тотыну

**ТӘГАЕНЛЕК** *и.* Ачыклык, аныклык, билгелелек. *Артык тәгаенлек һич ярамаганны белә торып, һаман шул засадага килеп төшә...* Х.Камалов. *Аның төп юнәлешләре дә билгеләнде, ләкин программа белән танышып чыккач, тәгаенлек җитешмәве күзгә ташланды.* Шәһри Казан

**ТӘГАҖҖЕП** *и. гар. иск.* **1.** Гаҗәпләнү хисе, хәйранлык. *Фәтхулла хәзрәтнең артык тәгаҗҗебенә каршы көзге адәм тавышы белән сөйли башлады.* Ф.Әмирхан. *[Әни] мәһабәт кыяфәттә булып, йөзендә ниһаясе булмаган хәйрәт вә тәгаҗҗеп балкый иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *хәб. функ.* Гаҗәп хәл, аптыраш. *Тәгаҗҗеп, әллә ул зат һәр нәҗесләрдән дә [начарракмы]?* Г.Тукай

**ТӘГАҖҖЕ́П ИТҮ** *ф. иск.* Гаҗәпләнү, ис китү, хәйран калу. *Җәгъфәр елый да елый, әмма әтрафындагылар я тәгаҗҗеп итәләр, я риялы сурәттә кызганган булалар.* Ф.Әмирхан. *Мин карчыктан бу хәлне күргәч, тәгаҗҗеп итеп, карчыкның янына якын килеп, алма шәрабеннән бер касә тутырып карчыкка бирдем.* Ф.Халиди

**ТӘГАҖҖЕ́П КЫЛУ** *ф. к.* **тәгаҗҗеп итү**

**ТӘГАМЬ** *и. гар.* Ашамлык, аш, ризык, азык. *Дәрвиш илә шаһзадә зур бер каекка һәртөрле тәгамьнәр төяделәр.* Ф.Халиди. *Дини аш мәҗлесендәге изге тәртипләр белән әзерләнгән тәгамьнән авыз иттек.* Р.Сибат

**ТӘГАМЬЛӘНҮ** *ф. иск. кайт. юн. к.* **тәгамьләү**

**Тәгамьләнә башлау** Тәгамьләнергә керешү. *[Юлчылар] ачыккан карыннарын туйдырмак өчен, хөрҗиндәге юл азыкларын алып, су буенда яшел чирәмгә утырып тәгамьләнә башладылар.* Ш.Мөхәммәдев

**Тәгамьләнеп алу** Тиз генә, аз гына тәгамьләнү

**ТӘГАМЬЛӘ́Ү** *ф.* Ризык кабул итү, тамак туйдыру. *Тотты да [бөркет] безнең батыр ябалакны Тәгамьләде чукып-чукып, йолкып-йолкып.* Г.Тукай

**ТӘГАССЫП** *и. гар. иск.* Теге яки бу идеягә, карашка сукырларча ышану; фанатизм. *Андагы фикерләр – XX гасыр*

*башында бөтен татар әдәбиятын сугарган фикерләр: татарларның артта калуы, --- гыйлемнең кирәклеге, тәгассып вә иске тормышның җимерелергә тиешлеге.* Т.Гыйлаҗев. *Бу төркемнәрнең һәрберендә бик көчле «кабилә тәгассыбы, ягъни фанатизмы» сакланып, һәрбер гарәп үз җәмәгатен күздә тота… Шул тәгассыб аркасында зур сугышлар, канлы вакыйгалар да мәйданга чыга.* Мирас

**ТӘГӘРӘГЕЧ** *и. а.х.* Сукаланган һәм чәчелгән җирне тигезләү һәм кантарларны вату өчен, цилиндр рәвешендәге, гадәттә тешле, тагылма авыл хуҗалыгы коралы; *русчасы:* **каток**. *Тәгәрәгеч буразналарга аркылы юнәлештә хәрәкәт иткәндә туфракның өслеге яхшырак тигезләнә.* Хәзерге авыл хуҗалыгы машиналары һәм алардан файдалану. *Тәгәрәгечнең дисклары тугымнарындагы ук юнәлешендә әйләнергә тиеш.* Механизатор белешмәсе

**ТӘГӘРӘЙ** *и. бот.* Көзен сабаклары кибеп, укмашып шар хасил итеп, тамырыннан аерылып, җил белән тәгәрәп, өлгергән орлыкларын чәчеп йөри торган төрле дала үсемлекләренең гомуми атамасы; өермә үләне, дүңгәләк; *русчасы:* **перекати-поле**

**ТӘГӘРӘП** *рәв.* 1) Тәгәрәү (*1 мәгъ.*) ысулы белән, тәгәрәү юлы белән. *Таптаза, туп шикелле тәгәрәп йөри торган җирләреннән я берәр чир әләгеп, яисә берәр төрле бәхетсезлеккә юлыгып үлә барган алар.* В.Нуруллин

2) *күч.* Җитез һәм йомшак хәрәкәтләр белән. *Тиктормас Актәпи, кәгазь кисәкләре белән уйнап, тере йомгактай тәгәрәп йөри.* Г.Сабитов

3) *күч.* Бик җайлы, каршылыксыз, уңышлы рәвештә (бару, тору, яшәү тур.). *– Эшләр майлагандай тәгәрәп бара, Катя, – дип, Петухов Кадриядән бигрәк үзен үзе юатып сөйләнде.* В.Имамов

4) *күч.* Иркен рәвештә, иркендә, рәхәтләнеп. *Мин Казаннан Ташлытау станциясенә кайтып төштем дә, караңгы төндә юлга чыгарга куркып, вокзал идәненә тәгәрәп йокладым.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Барлыклы, тыныч тормышта, рәхәттә. *Гаиләсе бөтен, балаларының тормышлары җайга салынган, оныклары тәгәрәп үсәләр.* Р.Мөхәммәдиев

**ТӘГӘРӘТЕШ** *и.* Берәр нәрсә тәгәрәтеп уйнала торган уен; гомумән тәгәрәтү эше, процессы. *Җәза салыш, капкалы уены, туп тәгәрәтеш!* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ТӘГӘРӘТҮ** *ф.* 1) Түгәрәк, йомры нәрсәне әйләндереп хәрәкәт иттерү. *Җиңги каймаклап-каймаклап чәй дә ясый, пешкән йомыркаларны да Вилдан алдына тәгәрәтә.* Г.Толымбай. *Мичкәләрне тәгәртеп төшерделәр дә, тиз генә Маннурны арбага салып, атны кире бордылар.* М.Хәсәнов

2) Берәр нәрсәне түгәрәк рәвешкә китерү, түгәрәк форма бирү. *Җепшек көнне балалар елдагыча тагын кар чүмәләләрен тәгәрәтеп уйнадылар.* Г.Толымбай. *Аның каравы балалар чана шуып, кар тәгәрәтеп рәхәтләнә икән.* Татарстан яшьләре

3) Йомшак массаны изгәләү, әвәләү; билгеле бер формага китерү. *Ак альяпкычын киеп ала да, яшьлек серләрен сеңдергән куна тактасына он сибеп, уңган камырны тәгәрәтә дә башлый.* Өмет. *Камырны 100–150 г лы кисәкләргә бүләләр дә бармак калынлыгында бау сыман тәгәрәтәләр һәм урман чикләвеге кадәр итеп турыйлар.* Татар халык ашлары

4) Тәгәрмәче, көпчәге булган нәрсәләрне хәрәкәт иттерү. *Олы капканы киң итеп ачып куйдык та тарантасны, тәгәрәтеп, урамга чыгардык.* И.Диндаров. *Хәтирәсенең коляскасын баскыч янына тәгәрәтеп китерде.* Безнең гәҗит

5) Нәрсәне дә булса төрле якка әйләндерү, бору, боргалау. *Ә кияве --- ашъяулыкка коелган икмәк вагын әле бер якка, әле икенче якка тәгәрәтеп-шудырып, аска карап утыра.* Ә.Әминев. *Гади уклауны аяк табаны астында тәгәрәтү бик файдалы.* Кәеф ничек?

6) Кемне яки нәрсәне аска табан бәреп төшерү, шудыру, төшереп җибәрү, аудару, ишү. *Аны [тәкәне] кызыл ярдан тәгәрәтү өчен, хәзер гайрәте арткан-нан-арта барган Микәйгә җиңелчә хәрәкәт ясап тагы бер кизәнү җитә.* Р.Мөхәммәдиев. *Ярның сөзәк урынын эзләп табып, яр урманында бүрәнәләр кисеп, аска тәгәрәтә башладылар.* Р.Батулла

7) Үзенең юлы, кысасы һ.б.ш. эчендә йөрткәләү, хәрәкәтләндерү. *Зәбихулла абый тәрәзә яңагына сөялгән дә, кысык күзләрен елтыр-елтыр тәгәрәтеп, әле беребезгә карый, әле икенчебезгә.* Г.Бәширов

8) *сөйл.* Нык ачып, түгәрәк формага китерү, акайту (күз тур.). *Кибетче күзләрен шардай тәгәрәтеп төбәлеп торды да яңгыратып көлеп җибәрде.* Ф.Җамалетдинова. *Аннары Иннокентий, күзләрен өскә тәгәрәтеп, үзалдына сөйләнә башлады ---.* З.Мәхмүди

9) *сөйл.* Мич төбенә яки көлгә салып пешерү. *Ләкин кышын балалар чана шуып, пешкән алма булып кайтышка, ул йортта мичкә тәгәрәтеп пешергән кайнар бәрәңге дә булмый.* М.Мәһдиев. *Ә 26 апрель көнне әти матур күлмәген кия, умач пешертә, мичкә бәрәңге тәгәрәтә.* Р.Газизов

10) *күч.* Бериш нәрсәләрне, берәр массаны бик тиз хәрәкәт иттерү. *Калын толымнардай дулкыннар тәгәрәтеп, безгә таба катер килә.* Т.Нурмөхәммәтов. *Зур боз кисәкләрен тәгәрәтеп кенә китерә.* Кызыл таң

11) *күч.* Бик тиз вакыт эчендә уйлап табу, барлыкка китерү, эшләп чыгару, ясау. *Күренеп тора: Сәйдәштән унике елга алданрак туып, ипине күбрәк ашап өлгергән Тинчурин тел сәхнәсеннән йомры сүзләрне тәгәрәтеп кенә тора, сүзгә кеше кесәсенә керми.* Р.Низамиев

12) *күч.* Яңгырату, кайтаваз барлыкка китереп тарату. *Станция артындагы куе имән урманы ят тавышны тәгәрәтә-тәгәрәтә еракка озатты: – Ту-ту-тутууу!* М.Мәһдиев

13) *күч.* Көрәшкәндә, сугышканда, кемне дә булса аяктан егу, торган җиреннән аудару. *Ярулла Сирайны тәгәрәтеп җибәрә, ул тагы, торып, әтәчләнеп килеп ябыша.* М.Фәйзи. *Истәлекләр таза, яшь солдат Гарифулланың яшел чирәмлектә нык кына бил алышып, Гатият абзыйны тәгәрәтеп чалуы белән тәмамланды.* М.Мәһдиев

14) *күч.* Хәрәкәт иттерү, алга этәрү. *Дөньяны шулар тәгәрәтә, ә Котлас,*

*язмышның әчелегенә какча кукрәген каршы куеп, мал таба...* Т.Гарипова

15) *күч.* Идарә вазифасыннан алып ташлау, урыныннан төшерү. *Әрәм булды, тәгәрәттеләр шул.* М.Хәсәнов. *КПСС Үзәк Комитетының беренче секретаре Никита Хрущёвны тәгәрәтеп, аның урынына яңа түрә килгәч һәм әүвәлгечә генсек дигән атаманы кайтаргач, матбугатта һәм радиода ипләп-ипләп кенә Сталин исемен хуплап телгә ала башлаганнар иде.* А.Тимергалин

16) *күч.* Сайлауларда каршы тавыш биреп, кемнең дә булса кандидатурасын төшереп калдыру

17) *күч.* Харап итү, юкка чыгару, әрәм итү. *Шушы хәшәрәт [алкоголь] нинди ир-егетләрне хур итеп ташлый. Башкайларын кылыч белән чапкандай гына тәгәрәтә.* А.Хәсәнов

18) *күч.* Үтерү. --- *озын каеш бау белән эт җитәкләп чаңгыда йөгергән немец солдатын Габдрахман автоматтан кыска гына чират белән атып тәгәрәтте.* З.Зәйнуллин. *Лаешта бик шәп дару бар. Тәгәрәтә генә теге шакшыларны [күселәрне].* Безнең гәҗит

19) *күч.* Дәрәҗәсен, сыйфатын һ.б.ш.ларны төшерү, кирегә җибәрү, артка этәрү. *Шулай ук шәхес ирреге кысылуы һәм иминлек юклыгы да илне түбән тәгәрәткән.* Безнең гәҗит

20) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса телгә алу, игътибар объекты итү, шуның белән эш итү. *Ул вакыттагы тәнкыйть гел бер үк исемнәрне тәгәрәтә торган иде.* Р.Батулла

**Тәгәрәтә башлау** Тәгәрәтергә тотыну. *Ала кондыз бер казыкны янбашы белән ярга таба тәгәрәтә дә башлады.* К.Тәхау. *Менә бәрәңгене берәмберәм чирәмгә тәгәрәтә башладым.* Г.Бәширов

**Тәгәрәтә тору** Әлегә тәгәрәтү; әледән-әле тәгәрәтү. *Мичкәне, туктататуктата, өстәл буйлап тәгәрәтә торгач, табын кабат җанланып китте.* Л.Зөлкарнәй

**Тәгәрәтеп алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз арада, бераз тәгәрәтү. *Уеным тукталып калгач, ул, мияулап, каймак үтенгәндә генә күтәреп карый торган яшел күзләрен тәгәрәтеп алды.* Ф.Яхин. *Радик тирә-якка күзләрен тәгәрәтеп алды.* М.Кәбиров

**Тәгәрәтеп бару** Даими рәвештә тәгәрәтү

**Тәгәрәтеп бетерү** Барысын да тәгәрәтү. *Җил чыкты да калган тамчыларны да тәгәрәтеп бетерде.* Р.Батулла

**Тәгәрәтеп җибәрү** Кинәт тәгәрәтү. *[Илдар] агач атны алып кереп, ишек төбеннән түргә таба тәгәрәтеп җибәрде.* Г.Гобәй. --- *баскычның кыл уртасында кукраеп утырган буш сыра шешәләрен ялгыш тәгәрәтеп җибәрдем ---.* А.Әхмәтгалиева

**Тәгәрәтеп йөрү** Һәрвакыт, һәр җирдә тәгәрәтү. *Буровой вышкаларын, тәгәрмәчләр куеп, рельстан тәгәрәтеп йөриләр.* Ш.Бикчурин

**Тәгәрәтеп карау** Уңай яки тискәре нәтиҗәсен белү өчен тәгәрәтү; тәгәрәтү тәҗрибәсе ясау. *[Якупов,] бодай башакларын өзеп алып, бармак битләрендә тәгәрәтеп карый да, кәгазьгә төреп, кыр сумкасына сала.* Г.Гобәй. *Ул елны авылыбыз малайлары яңа уенчык уйлап тапты: таякка түгәрәк калай каккannар да, таягыннан тотып, шуны күтәреп йөриләр. Аңардан сорап алып, мин дә тәгәрәтеп карадым.* Безнең гәҗит

**Тәгәрәтеп килү** Билгеле бер вакыттан башлап тәгәрәтү; тәгәрәтү эшен дәвам итү

**Тәгәрәтеп кую** Бер мәртәбә тәгәрәтү; көтмәгәндә тәгәрәтү. *Ачулары килеп, түбәнгәрәк тә тәгәрәтеп куюлары бар.* К.Кара

**Тәгәрәтеп тору** Берөзлексез, гел, даими тәгәрәтү; хәзерге моментта тәгәрәтү. *Милләтеңнең демографик һәлакәтен җаның белән тойган килеш, яңа буынның үз телебездән бизә баруын күрә торып, бер-бер артлы әдәби әсәрләр тәгәрәтеп тору өчен яхшы мәгънәдә графоман булу кирәк.* Р.Зәйдулла

**ТӘГӘРӘ́Ү** *ф.* 1) Үз күчәре тирәсендә әйләнә-әйләнә хәрәкәт итү (түгәрәк, йомры нәрсәләр тур.). *Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, әбекәй?* Әкият. *Кырлар буенча, йомарланып, бүре уты тәгәри.* К.Нәҗми

2) Тәгәрмәчләргә утыртылган арба, машина һ.б.ш. нәрсәләр хәрәкәт итү, бару. *Арба җиксәң – тәгәрәми, чана җиксәң – шумый.* Г.Бәширов. *Юл дымсурак булгангадыр күрәсең, тәгәрмәчләр дә тигезрәк тәгәрәгән шикелле, арба дыңгырдамый.* В.Имамов

3) *сөйл.* Мәтәлү, егылу, түбәнгә авып төшү. *Димәк, Арчага кергәндә, әтисе очып төшеп калган. Юлдан читкә тәгәрәгән булса, берни дә юк, ике якта йомшак уҗым басуы иде.* М.Мәһдиев. *Дәү тәкә кызыл яр астына тәгәрәүдән исән-сау котылу куанычыннан кәҗәләренә күз төшереп алды.* Р.Мөхәммәдиев

4) Аунау. *Ана, үз-үзен белештермичә, җирдә тәгәрәп, туң балчыкны тырный иде.* В.Гали. *Әй рәхәт инде, малай, хуш исле печән өстендә тәгәрәве!* И.Диндаров

5) Тамчы-тамчы булып агып төшү (тир, күз яше тур.). *Кызның күзләре уйчанланып китте. Ул да булмады, бит алмалары буйлап эре-эре күз яшьләре тәгәрәде.* М.Хәсәнов. *Әлеге эш коралларында ул әтисенең кул җылысын, --- чигәсеннән тәгәрәп тамган тир кайнарлыгын тоя иде кебек.* Р.Мөхәммәдиев

6) *күч.* Бик тигез, салмак кына хәрәкәт итү (гадәттә күк җисеме тур.). *Офык читеннән салмак кына тәгәрәп күтәрелгән алсу шарга Кар кызы баштарак әллә ни игътибар итмәгән.* Г.Гыйльманов. *Көтү кайтып, кояш офыкка тәгәрәгән мизгелдә, ике малай, кулларына берәр метрлы кадаксуыргыч тотып, иске мәктәпкә килеп керде.* А.Гыймадиев

7) *күч.* Бик кызу чабу, йөгерү, хәрәкәтләнү (кыска буйлы кешеләр һәм хайваннар тур.). *[Әхмәди:] Их сине, малай актыгы! Төкер син аның шартлавына! Син алай сузылып ятма, үрмәләвеңне бел, алга тәгәрә!* Г.Бәширов. *Шапырай карт искиткеч җитезлек белән терт-терт атлап урам буенча китте: тәгәрәп кенә бара.* М.Хәсәнов

8) *күч.* Нык ачылу, түгәрәкләнү, акаю; шул килеш хәрәкәтләнү (күз тур.). *Ул мондый вакытларда бертуктамый як-ягына карый, аның соры күзләре мәгънәсезгә тәгәриләр.* Г.Толымбай. *Күзләре уңга-сулга тәгәри: кайда соң бу чукынган Хәбир, ни өчен минем җиңүемне күрми?* З.Мурсиев

9) *күч.* Йокыга китү. *Инде Йосыф та, тыңлый-тыңлый йоклап киткән сеңелесен уятып, өенә алып чыгып китте, энем күптән тәгәрәгән, мин ялгыз калып, йокы белән көрәшә-көрәшә укып утырдым.* Г.Гобәй

10) *күч.* Яңгырау, кабат-кабат кайтаваз барлыкка китерү. *– Җәмәгать, Сәлим ага килгән! – дигән хуплау тавышлары тәгәрәде.* М.Галәү. *Тавыш, ачык күл өстендә тәгәрәп китеп, урманга барып керде.* Г.Исхакый

11) *күч.* Тоткарлыксыз, каршылыксыз, яхшы, уңышлы бара бирү (тормыш, эш һ.б.). *Минем эшләр ипле генә тәгәри дә тәгәри.* В.Нуруллин. *Эшләр шулай матур гына тәгәрәгәндә, Ерак Сахалиннан Фәннурның геолог абыйсы кайтты.* А.Гыймадиев

12) *күч.* Сиздермичә үтү. *Бөтен тормыш бик тиз тәгәри.* Б.Ибраһим. *1969 елда «Запорожец» машинасы бирделәр. Еллар әкренләп шулай тәгәрәде.* Әтиемнең тутыкмас ядкәре

13) *күч.* Саны, сыйфаты һ.б.ш. күрсәткечләре нык төшү, кимү. *Сатучылар күп, ә алучы аз булганлыктан, бәяләр бик тиз түбән тәгәрәде.* М.Галәү. *Зөфәр атаманлык иткән уку сыйныфында тәртип аска тәгәрәгәннән-тәгәрәде.* З.Зәйнуллин. *Елдан-ел аска тәгәрәгән тираж да бер мизгелдә күтәрелеп китәр иде.* Д.Гыйсметдин

14) *күч.* Сайлауларда аз тавыш алып, төшеп калу

15) *күч.* Рәте китү, чуалу, киреләү, начар якка үзгәрү (тормыш, эшләр һ.б.ш. тур.). *Тартасыз инде, эшегез һаман тау астына тәгәри.* А.Алиш

16) *күч.* Ахыргы урынга күчү, алдынгылыктан төшү; гомумән ирешелгән дәрәҗәне югалту. *Үзем дә сизмәстән, тормыш үренә менеп барган җиремнән аска тәгәрәп төшеп киттем.* А.Мансуров. *Әгәр без иптәш Зайцевка тагын да азынырга ирек куйсак, ел йомгаклары буенча иң арттагы урыннарның берсенә тәгәрәү – котылгысыз хәл.* В.Имамов

17) *күч.* Властьтан мәхрүм калу, эш урыныннан азат ителү, вазифадан төшерелү. *Мөдирлектән тәгәрәү*

18) *күч.* Берәр якка чыгып китү, китеп бару, ычкыну, олагу. *Төн булып беткән иде инде. Бай, хәерле кичләр теләп, арбасы белән тәгәрәде.* М.Галәү. *Я, я, күп телеңә салынма. Тәгәрә моннан, әйдә, әйдә, тәгәрә.* Ш.Камал

19) *күч. сөйл.* Үлү, һәлак булу. *Немец кола япанда атакага чыкса, салкыннан катып тәгәрәгәнче, аның вакыты бернечә сәгать кенә...* З.Зәйнуллин. *Ачка тәгәрәсәләр дә кызганмау*

◊ **Тәгәрә дә үл!** Гарьләнү, оялу, чарасыз калу һ.б.ш.ларны белдерә. *Улы атасына каршы шундый сүз әйткән әле. Хурлыгыңнан тәгәрә дә үл!* Н.Исәнбәт. *[Васфикамал:] Тәгәрәп үлсәм үләрмен, сез ужым бозауларын рәткә салырмын!* М.Мәһдиев. **Тәгәрәгәнче ашау** Күп итеп, гарык булганчы ашау. **Тәгәрәгәнче көлү** Бик каты көлү. *Үзе генә тәгәрәп көлә, башкалар аның көлгәнен карап торалар.* А.Гадел. **Тәгәрәп китү** Берәр нәрсәгә нык гаҗәпләнү, соклану, гаҗәпләнү һ.б.ш. турында. *Әгәр Гүзәлне Шакир абыегыз күрсәме, билләһи газыйм, тәгәрәп китәчәк.* Г.Галиева. --- *арзанлы зонтиклар сатып торган картны күреп, тәгәрәп китә язды.* М.Кәбиров

**Тәгәрәп алу** Бераз тәгәрәү

**Тәгәрәп бару** Тәгәрәү алдында тору, тәгәри башлау. *Син китап күп укысаң да, акылга сай кеше идең, хәзер инде бөтенләй түбәнгә тәгәрәп барасың.* З.Хәким

**Тәгәрәп йөрү** Бертуктаусыз тәгәрәү. *Шар кебек тәгәрәп йөргән малайның әтисе кем?* А.Хәсәнов

**Тәгәрәп китү** Кинәт тәгәри башлау. *Арбалар тау астына кирегә тәгәрәп китмәсеннәр өчен, тәгәрмәч аслары-на агачлар кыстырдык.* Г.Ибраһимов. *Кемнәрдер баскычтан мәтәлә-кадала аска таба йөгерешә. Егылганнары тәгәрәп-тәгәрәп китә.* И.Гази

**Тәгәрәп тору** Бертуктаусыз тәгәрәү; хәзерге моментта тәгәрәү. *Тәгәрмәчләрегез келтер-келтер тәгәрәп тора, аякларыгыз тыпыр-тыпыр атлап бара, авырсына күрмәгез инде, оланнар ---.* М.Кәрим

**Тәгәрәп яту** Тәгәрәгән хәлдә булу. *Тагын хәтеремдә: көзли дуңгыздай тәгәрәп яткан ак кабакларны, өзеп, каралты башына тезүләр.* И.Гази. *Бәрәңгенең ара-тирә шәмәхә кабыклысы да була: анысы, кабыгын салгач, ап-ак мәрмәр кисәге кебек шалтырап тәгәрәп ята.* М.Мәһдиев

**Тәгәри башлау** Тәгәрәргә тотыну. *Фатыйманың ябык битләре буйлап кинәт яшь тәгәри башлады.* И.Гази. *Приборлар авыруның хәле нормаль икәнен күрсәтеп торалар иде. Кинәт стрелкалар сикереп куйды. Аннары бик кызу түбән тәгәри башладылар.* Г.Әпсәләмов

**Тәгәри бирү** Бернигә карамый тәгәрәвен дәвам итү. *Вакыт арбасы үз көенә тәгәри бирә.* А.Хәсәнов. *Атлар абзарында тормыш үз көенә тәгәри бирә.* В.Имамов

**Тәгәри тору** Әлегә тәгәрәү; әледән-әле тәгәрәү. *Тормыш акрынлап тәгәри торды, элекке кебек тормыш авыр, ачылангач түгел.* З.Кадыйрова. *Тормыш арбасы үз көенә тигез келтерәп тәгәри торды.* К.Кара

**Тәгәри төшү** Бераз тәгәрәү; тагын да ныграк тәгәрәү

**ТӘГӘРӘШҮ** *ф. урт. юн. к.* **тәгәрәү**. *Анда, тәгәрәшеп, Рәдифнең энеләре йоклый.* М.Мәһдиев. *Җебе шартлап өзелгән кызыл муенсаның вак-вак төймәләре тузанлы чирәм арасына тәгәрәште.* Н.Гыйматдинова

◊ **Тәгәрәшеп китү** *к.* **тәгәрәп китү**. *Кызлар исә тәгәрәшеп китә яздылар.* М.Хәсәнов

**ТӘГӘРИ** *и. диал. к.* **тәгәрәй**

**ТӘГӘРМӘЧ** *и.* 1) Арбаларның һәм һәртөрле машиналарның күчәрендә әйләнеп, аларны хәрәкәтләндерергә хезмәт итә торган кигиле яки тоташ түгәрәк; көпчәк. --- *Бастырык басасы бауны арбаның арт тәгәрмәче тугымына чорныйбыз да атны кузгатабыз. Тәгәрмәч, бастырык бавын үзенә чорнап, шыгырдатып йөкне бастыра.* М.Мәһдиев. *Һәм ул тирә-якка ак кар бөркеп, салкыннан булса кирәк, тәгәрмәчләрен гадәттәгедән катырак шыгырдатып килгән пассажир поездын каршы алды.* М.Хәсәнов

2) Төрле механизмнарда аларның аерым өлешләрен хәрәкәткә китерергә, әйләндерергә ярдәм итә, арадашчы тапшыргыч ролен үти торган шуңа охшаш деталь. *Физика кабинетында*

*электр тогы ясый торган бер машина бар. Шуның аксыл тәгәрмәчен бик каты әйләндергәч, металл щёткалары чорт-чорт киләләр.* М.Мәһдиев. *[Тракторда] һәр ян йөрткечкә өчәр тешле юлдаш тәгәрмәч куелган.* Тракторлар һәм автомобильләр

3) Пароходны суда хәрәкәтләндерә торган җайланма; чарык. *Матрослар, бик җитез кыланып, басмаларны тартып алдылар; трослар ычкындырылды, иннек ябылды, һәм канатлы тәгәрмәчләр, суга шап-шоп бәреп, башта әкрен генә, аннары һаман ныграк, кызурак әйләнә башладылар.* Н.Фәттах. *Җәенке сары буксир кисәге, көчәнеп, --- суны тәгәрмәч такталары белән шапыр-шопыр айкый.* Казан утлары

4) Яссы түгәрәк рәвешендә киселгән, ясалган әйбер, гомумән шул формадагы предмет. *Утын әрдәнәсеннән байтак әйбер җыйдым. Нарат, юкә, имән, каен бүкәннәреннән берәр тәгәрмәч кисеп алдым.* М.Мәһдиев. *Ике тәгәрмәч сыр, ике тәгәрмәч казылык кисү*

5) Гәүдәнең авырлыгын аяклардан кулларга күчереп, гәүдәне алга атып баш аркылы әйләнүдән гыйбарәт акробатик күнегү. *Сәхнәдә тәгәрмәч ясау*

6) *күч.* Бертуктаусыз хәрәкәт иткән, үзгәртеп, туктатып булмый торган процесс, күренеш. *Тарих тәгәрмәчен борып булмый, Кире боралмыйсың, тырышма!* Н.Әхмәдиев. *Дөнья тәгәрмәче сыта ул йомшакларны.* Н.Гыйматдинова

◊ **Тәгәрмәче шәп әйләнү** *к.* **тәгәрмәче шәп эшләү**. **Тәгәрмәче шәп эшләү** Зирәк, үткен, булдыклы кеше турында. **Тәгәрмәчкә таяк тыгу** Эшкә комачаулау, аяк чалу. *Шулай да бу көчле, белемле һәм шактый талантлы тәти егет, бик күп кешеләрнең тәгәрмәченә таяк тыгып, аларны вакытлыча гына булса да эштән аерып торырга мәҗбүр итәчәк әле.* Г.Рәхим. *Ләкин шуннан соң да аны еллар буенча тинтерәтеп йөрттеләр: әле бер оппоненты, әле икенчесе, иске исәп-хисапларны казып чыгара-чыгара, тәгәрмәчкә таяк тыкты.* Г.Әпсәләмов. **Тәгәрмәчкә эләккән тиен кебек** Бәлагә, мәшәкатькә күмелеп яшәгән кешегә карата. *Тәгәрмәчкә эләккән тиен кебек әйләнәсеңме? Әйлән, әйлән. Үз тәгәрмәчеңә үзең эләктең!* Г.Әхмәт. **Тәгәрмәчтәге тиен кебек** *к.* **тәгәрмәчкә эләккән тиен кебек**. *Хәзер Коста тәгәрмәчтәге тиен кебек бөтерелә, хәер, шеф үзе дә сауналарда кәеф-сафа чигеп ятмый, спорт мәйданчыкларында җилләнеп йөрми, ләкин эш белән кызыксынуы күзгә күренеп кими бара иде.* Р.Мирхәйдәров. **Тәгәрмәч эзгә төшү** Эшләр җайлана башлау, нормаль хәлгә килү, юлга салыну. *Тәгәрмәч эзгә төшә алмый. Тәгәрмәч юлын үзгәртеп торалар шул.* Н.Исәнбәт

**ТӘГӘРМӘЧЛӘП** *рәв.* Түгәрәкләп, тәгәрмәч рәвешенә китереп. *Мендә беркөнне ул, тәгәрмәчләп кенә турап, ярмалы ак әмерхан бәрәңге пешерде дә ялгыз чәйгә утырды.* М.Мәһдиев. *Бәрәңгене, суганны тәгәрмәчләп турыйбыз.* Татар халык ашлары

**ТӘГӘРМӘЧЛЕ** *с.* **1.** 1) Тәгәрмәч ярдәмендә хәрәкәт итә торган. *Бернигадәр вакыт үтүгә, атларын җир өстендә калдырып, Дулдин Хәйбушенең тешле тәгәрмәчле тракторына төялгән малайлар төшеп җиттеләр.* З.Зәйнуллин. *Шунда, юл читендә, капламалы өч тәгәрмәчле мотороллер торганлыгын шәйләп алды.* Д.Бүләков

2) Тәгәрмәче булган, тәгәрмәч куелган, тәгәрәтеп йөртелә торган. *Ул арада тәгәрмәчле ятакны тәгәрәтеп керттеләр.* М.Маликова. *Аны иплән кенә тәгәрмәчле өстәл өстенә салдылар да палатадан алып чыгып киттеләр.* Р.Вәлиев. *Тәгәрмәчле чемоданын егет утыргычка ук терәп куя ---.* Р.Гаязетдин

3) *күч.* Транспортлы, берәр транспорт чарасы булган. *Курсташлар машиналар алган чакта, мин дә тәгәрмәчле булдым...* Д.Гыйсметдин

**2.** *и. мәгъ.* Тәгәрмәч тәгәрәтеп уйнала торган уен. *Тәгәрмәчле уйнаган вакытта, кем иң беренче булып тәгәрмәчне урам буйлап тәгәрәтеп җибәрә?* Р.Газизов

**ТӘГӘРМӘЧЛЕК** *с.* **1.** Тәгәрмәч ясар өчен яраклы, яки шуңа җитәрлек. *Ике тәгәрмәчлек карама агачы әзерләү*

**2.** *и. мәгъ.* Шуңа яраклы материал. *Тәгәрмәчлекне көздән әзерләү*

**ТӘГӘРМӘЧСЕЗ** *с.* **1.** 1) Тәгәрмәче булмаган, тәгәрмәчләр булуы күздә тотылмаган

2) Тәгәрмәче төшкән, тәгәрмәчләре алынган. *Гардеробсыз хатын тәгәрмәчсез машина шикелле инде ул...* Э.Яһудин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тәгәрмәчтән башка; тәгәрмәче булмаган хәлдә. *Шушы кадәр араны тәгәрмәчсез ничек үткәннәр алар?* А.Гыйләҗев. *Мөсәмирә караса, аптырап китте: үз сабанының бер тәгәрмәче юк икән. Тәгәрмәчсез ничек әйләнгәндер ул?* Р.Кәрами

2) *күч.* Транспортсыз. *Ә тәгәрмәчсез калдыңмы, хезмәт көне – түтүт, печән, утын – түтүт.* Р.Газизов

**ТӘГӘРМӘЧЧЕ** *и.* Тәгәрмәч ясаучы оста

**ТӘГӘРЧЕК** *и. диал. к.* **тәгәрмәч**. *Тәгәрчек әйләнсә, көпчәгенә көч төшәр.* Мәкаль

**ТӘГӘЧ** *и. диал.* 1) Кымыз яки чәй эчәр өчен, өскә таба киңәйтеп эшләнгән кечкенә агач савыт; йомры. *Бер юлаучы булып, ыругның олы аталарында берәр тәгәч кымыз эчеп чыктым.* Г.Ибраһимов

2) Кечкенә табак, коштабак

**ТӘГЪБИР** *и. гар.* 1) Нинди дә булса мәгънә яки фикер белдергән сүз тезмәсе, гыйбарә. *Бездә бирәк тә «латыш укчылары» дигән тәгъбир нык таралган. Һәм бу безнең өчен нык табигый да.* Р.Фәйзуллин. *Габдулла Тукаевның шигырьләрендә сүзләр һич тә чуалчык түгел, вәзеннәр җиңел, мәгънәләр ачык, тәгъбирләр матур...* Т.Гыйлаҗев

2) Берәр нәрсәне сөйләп аңлатып бирү, ачыклау. *Шуларның димләүләре аркасында мин дә март аенда --- бер кыргыз авылында мулла (шул вакытның тәгъбире буенча) булып чыктым.* М.Гафури. *Үз тәгъбиренчә әйтсәк, аның малдан, игеннән бәхете дә бар иде.* Г.Ибраһимов

3) Төшкә мәгънә бирү, төш юрау. *Падишаһ Йосыфны үз янына чакыртты, тәгъбирне кабаттан сорады.* Пәйгамбәрләр тарихы. *Тәгъбирендә хата булу. Тәгъбиргә ышану. Тәгъбир һәм фалга бәйләнешле китаплар*

**ТӘГЪБИР ИТҮ** *ф.* Сүз белән билгеләү, сүз ярдәмендә белдерү, әйтеп

бирү, аңлату. --- *һичбер төрле үлчәүгә сыя алмаслык бер сүз әйтеп, үземнең хәзерге хәлемне тәгъбир итәсем килдеме: ни дә булса гадәттән югары бер ташкынлы теләгем бар иде.* Г.Ибраһимов

**ТӘГЪБИРЛӘ́Ү** *ф. к.* **тәгъбир итү**. *[Ул] сәгадәт ташкыннарын --- тәгъбирләргә зиһен вә тәкать китерә алмый.* Г.Ибраһимов

**ТӘГЪБИРНАМӘ** *и. гар.-фар.* Төш юрау китабы. *Тәгъбирнамәләр Казанда 1847 елдан башлап --- өзлексез басылып килгәннәр.* А.Тимергалин

**ТӘГЪБИРЧЕ** *и.* Төш юраучы. *Падишаһ тәгъбирчеләрне дәште, аларга барысын да сөйләп бирде.* Пәйгамбәрләр тарихы

**ТӘГЪҖИЛ** *и. гар. иск.* Ашыктыру, тизләтү; ашыгычлык; тәҗел. *Тәгъҗил берлә Йосыфә йитә алмазсән.* Кол Гали

**ТӘГЪҖИ́Л ИТҮ** *ф.* Ашыгу. *Әсгадьнең анасы әйтте: --- – Безнең Гайнелхәятның көфуы бардыр. Нигә тәгъҗил итәсез?* Ф.Халиди

**ТӘГЪЗИЯ** *и. гар. кит.* 1) Үлгән кешенең якыннарының кайгысын уртаклашып, сабырлык теләү. *Тәгъзиягә бик күп кешеләр килгәннәр иде.* Г.Исхакый

2) *к.* **тәгъзиянамә**. *«Төрек йорды», «Төрек сүзе», «Кырым» кебек госманлы газета-журналларында тәгъзияләр, татар шагыйре турында кечкенә күләмле мәгълүматлар басыла.* А.Мөбарәкшина

**ТӘГЪЗИЯ́ ИТҮ** *ф.* 1) Үлгән кешенең якыннарының кайгысын уртаклашу, сабыр булырга өндәү

2) Тынычландыру, юату. *[Бүлмәмә] барып керү белән аптырый калдым, гүя мин ничә айлар монда булганым юк иде; гүя ул мине ни өчендер тәгъзия итте.* Г.Ибраһимов

**ТӘГЪЗИЯ́ КЫЛУ** *ф. к.* **тәгъзия итү**. *Дустыңның вафатына тәгъзия кылу*

**ТӘГЪЗИЯНАМӘ** *и. гар.-фар. кит.* Берәүнең вафатыннан соң кайгы уртаклашып язылган мәкалә, хат; некролог

**ТӘГЪЗЫЙМ** *и. гар. иск.* Кемне дә булса олылау, зурлау; хөрмәт, ихтирам. *Рәхимовларның киң, бизәүле тормышлары Хәятта боларга каршы зур күрү (тәгъзыйм) тойгысы кузгата иде.* Ф.Әмирхан. *Мирсәяф хәзрәт кергән вакыттагы тынлык, аңа булган хөрмәт, аны тәгъзыйм белән каршы алу --- искиткеч иде.* Г.Гафури

**ТӘГЪЗЫ́ЙМ ИТҮ** *ф. иск.* Олылау, зур күрү, ихтирам итү, хөрмәтләү. *Чыксам сахрага, гөлләр, үләннәр тәгъзыйм итәләр, биреп сәламнәр.* Ш.Бабич

**ТӘГЪЗЫ́ЙМ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәгъзыйм итү**. *Үзем дә бераз укыган шәкерт, дигән уй белән, хәзрәткә каршы барып, тәгъзыйм кылып сәлам бирдем.* М.Гафури

**ТӘГЪЗЫЙМЛА́У** *ф. иск. к.* **тәгъзыйм итү**

**ТӘГЪЛИКЪ** *и. гар.* Гарәп язу өлгеләренең фарсылар арасында киң таралганнарыннан берсе. *[Г.Ильясиның] каләме яхшы булып, бигрәк тә ул тәгъликъ язуына оста икән.* Гали Рәхим

**ТӘГЪЛИМ** *и. гар. иск.* Өйрәтү, укыту, белем бирү яки алу эше. *Хәзерге вакытта башка милләтләр арасына кереп эш эшли алмак өчен, күзе ачык, мәгълүматлы, русча һәм мөселманча мөкәммәл тәгълим алган кеше булмак кирәктер.* Икътисад

**ТӘГЪЛИМАТ** *и. гар.* Яшәешнең, фәннең берәр өлкәсенең нигезен тәшкил иткән теоретик кагыйдәләр, күрсәтмәләр системасы; нигез булырлык принциплар; доктрина. *Чыннан да, Гайсә пәйгамбәрнең тәгълиматы яһүдиләрнең традицион диненнән күп ягы белән аерылып тора.* С.Шәмси

**ТӘГЪЛИ́М ИТҮ** *ф.* Өйрәтү, укыту, белем бирү. *Монда [Троицкида], әлбәттә, уку дигән нәрсә күбрәк Бохара ысулында, иске хорафатлар һәм дини әсәрләр укудан, боларны да иң тәртипсез рәвештә тәгълим итүдән гыйбарәт иде.* М.Гафури. *Гайшә --- авылның яшь кызларына кыйраәт вә китабәт тәгълим идеп, киләчәк заманга тәрбияле аналар хәзерләмәктә иде. Бу мәдрәсәдә [Буби] голүме диниядән башка җәгърафия, тарих һәм рус теле дә тәгълим итәләр.* Мирас

**ТӘГЪРИЗ** *и. гар. иск.* 1) Ризасызлык, каршылык, протест

2) Читләтеп әйтү, киная. *Ул [Тукай] бөек уй, нечкә хис, тәгърizләргә бик бай, димен. Бар урыннарда аның урынын кадерле, дәү, димен.* Ш.Бабич

3) Каршы тору

**ТӘГЪРИ́З КЫЛУ** *ф. иск.* 1) Ризасызлык белдерү. *Шәһәремне сорама, дип тәгъриз кылды.* К.Насыйри

2) Каршы тору. *Бәндәңез җавап бирдем: – Гаскәрләргә лазем, олугларына итагать кылып, һәрвакыт тәгъриз кылмый, --- дошманга аслан рәхим кылмаска, – дидем.* Ф.Халиди

**ТӘГЪРИФ** *и. гар. иск.* 1) Берәр нәрсәнең сүз белән аңлатылышы, сүздәге тасвирламасы. *Башка вакыт шуйлә тәгъзыйм вә гыйззәт итәр иде, тәгърифе мөмкин түгел.* Ф.Халиди

2) Билгеләү; аңлатма, билгеләмә. *Дөрес, бу кыска тәгъриф миллият кеби тирән вә әтрафлы бер төшенчәне бөтен нигез, билгеләре илә ачып бирә алмас.* Җ.Вәлиди. *Мин хөкүмәт документларының берсендә панисламизмның тәгърифен шулай таптым.* С.Максуди

**ТӘГЪРИ́Ф ИТҮ** *ф. иск.* 1) Берәр нәрсә турында сөйләп аңлату, аңлатып, төшендереп бирү. *Ул хәлдә миллиятне «кан, дин, тел, гадәт вә ганганә кеби әсасларның берлеге сәбәпле бергә җыелган кешеләр җәмгыяте» диеп тәгъриф итсәк, шаять ялгышмамыз.* Җ.Вәлиди

2) Берәр җанлы-җансыз нәрсәнең тышкы күренешен, кыяфәтен сурәтләү, тасвирлап бирү. *Мәхүп Гайшәне Габбаска шулкадәр тәгъриф итте ки, Габбас Гайшәне ике мәртәбә күрсә дә, бу кадәр мәхәббәт хасил булганы юк иде.* З.Һади. *Тулпарны халык болай тәгъриф итә: ул карап торуга юаш кына, --- үзе канатлы була, имеш.* Ш.Бабич

**ТӘГЪРИ́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәгъриф итү**. *Үз хәлеңне белми, Басрадан кайтып, Габделмәлик хакимнең кызы Дәһханәне миңа тәгъриф кылдың.* Ф.Кәрими. *Тәхеттә утырган кыз кәлимә агыз итеп әйтте: – Бу тәхетнең өстендә бер егет күрдем. Моның матурлыгына йөз мең ел гомерем булса да тәгъриф кылып бетерә алмас идем.* Ф.Халиди

**ТӘГЪРИФЛӘ́Ү** *ф. иск. кит. к.* **тәгъриф итү**

**ТӘГЪРИФНАМӘ** *и. гар.-фар.* Каталог

**ТӘГЪТЫЙЛЬ** *и. гар. иск.* Каникул (мәдрәсәләрдә), ял итеп тору вакыты. *Гали җәй көне, тәгътыйль ва-*

*кытларында, атасы янында заводта сабын пешерергә өйрәнә торган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Каникул дип тәгътыйль вакытына әйтәләр.* Ф.Кәрими

**ТӘДБИР** *и. гар. кит.* 1) Берәр хәл, эш-гамәл өчен алдан уйлап күрелгән чара, әзерлек; хәстәрлелек, мәнлелек, уйлап эш итүчәнлек. *Гайшә килен улса да, Габбасның тәдбире саясендә һичбер мәшәкать күрми, вакытыны хушлыкта үткәрә иде.* З.Һади. *Минем тел әүвәл гаять тупас вә нәзакәтсез иде. Соңга таба дөньяны күрә килә әзрәк шомарырга, төзәлергә бит алды. Хәйлә, мәкер, тәдбирне аз-азлап белә башлады.* Ш.Бабич

2) Мәсьәләне хәл итү чарасы, берәр хәлдән чыгу юлы, әмәле. *Бу сүздин соң падишаһ әйде: «И яранлар, бу эшнең тәдбире ни булыр?!»* Дастан. *Гайнелхәят кәнизәкнең бу тәдбирене кабул итеп, хазир безләрне сарайга дәгъват итте.* Ф.Халиди

**ТӘДБИ́Р ИТҮ** *ф. иск.* Берәр нәрсәгә ирешер өчен кирәкле эш башкару, тиешле чарасын күрү, хәстәрләү, әмәлен табу. *Адәм тәдбир итәр, Аллаһ Тәгалә тәкъдир итәр.* Мәкаль

**ТӘДБИ́Р КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәдбир итү**. *Тәдбирен кылалмаган тәкъдиргә сылтар.* Мәкаль. *Чөнки безнең бу хәрәкәтләребезгә каршы тору өчен кылынган тәдбирләр панисламизм бар дип уйланганнандыр.* С.Максуди

**ТӘДБИРЛЕ** *с. кит.* **1.** Уйлап эшләүче, алдан күреп эш итүчән. *Тарих белгән кемсәләр артык тәҗрибәле вә тәдбирле булалар.* Г.Әхмәров. *Бу баланың өстенә-башына караганда, атасының фәкыйрьлеге белендеке кеби, өйләрендә бер тәдбирле бала караучы барлыкны да белдерә иде.* З.Һади

**2.** *рәв. мәгъ.* Эшне алдан уйлап, хәстәрен күреп, әзерлекле рәвештә

**ТӘДБИРСЕЗ** *с. гар. кит.* **1.** Алдагысын уйламыйча, эшнең ахырын исәптә тотмыйча эш итүчән

**2.** *рәв. мәгъ.* Эшне алдан уйламыйча, хәстәрен күрми торып, әзерлексез, мәнсез рәвештә

**ТӘДБИРСЕЗЛЕК** *и. кит.* Алдагысын уйлап эшләмәү, акылсыз эш итү күренеше, ваемсызлык, мәнсезлек

**ТӘҖӘССЕМ** *и. гар. иск.* Нинди дә булса идея һ.б.ш.ның берәр җисемдә гәүдәләнү, гәүдәләндерелү күренеше; җисемләштерү; нәрсәнең дә булса чагылышы, гәүдәләнеше. *Тулы тәҗәссем*

**ТӘҖӘССЕ́М ИТҮ** *ф. иск.* 1) Күз алдына китерү; кемне яки нәрсәне дә булса гәүдәләндерү. --- *халык эчендә булган иҗат вә сәнгать орлыклары яңа шагыйрьләр, хикәячеләр кыяфәтендә тәҗәссем итә, үсә башлады, яфрак атты, инде чәчәкләр дә күренә.* Г.Ибраһимов

2) Берәр матди формада күз алдына килү, гәүдәләнү. *Ләкин әле һаман тынычлана алмыйм, һаман шул хыялымда тәҗәссем итә вә тирәнәя килгән базларны үзем дә сизми үтеп киләм.* Ш.Камал

**ТӘҖВИД** *и. гар.* 1) Коръәнне дөрес итеп уку турындагы белем. *Әмма берникадәр вакытка ул Каһирәдә кала һәм анда тәҗвид гыйлеменнән дәресләр ала.* Фәнни Татарстан. *Аудио Коръән бөтен тәҗвид кагыйдәләре, мәкам буенча дөрес итеп эшләнелгән.* Казан утлары

2) Коръән укуның орфоэпик кагыйдәләре язылган китап. *Ысулы җәдид яңа тарала башлап, --- тәҗвид укулар мәдәниятка таба бик зур адым дип танылган бер заманда --- һәммә иптәшләреннән алда бара.* И.Кули

3) *күч. сөйл.* Берәр эш-шөгыльнең нечкәлекләре. *Эшенең бөтен тәҗвиден белә*

**ТӘҖВИДЛӘП** *рәв.* 1) Тәҗвид кагыйдәләрен җентекле рәвештә саклап, тәҗвид кагыйдәләрен бозмыйча. *Дин гыйлемен үзләштерергә теләгән Азнакай балалары ураза ае дәвамында «Бәкара» сүрәсеннән бер битне тәҗвидләп укырга өйрәнделәр.* Дуслык

2) *күч.* Җиренә җиткереп, тиешенчә, бөтен кагыйдәләренә туры китереп. *Ул бөтен эшне тәҗвидләп эшли иде.* Мәдәни җомга

**ТӘҖВИДЛЕ** *с.* Тәҗвиде булган; тәҗвид кагыйдәләре күрсәтелгән. *Тәҗвидле һәфтияк*

**ТӘҖВИДЧЕ** *и.* Тәҗвид белгече, тәҗвид укытучы; тәҗвид дәреслеге авторы. *Тәҗрибәле тәҗвидче*

**ТӘҖЕ** *и. рус* Тәгәрмәч күчәренең очыннан тәртә башына тарттырып куела торган бау яки тимерчыбык; тәртә бавы. – *Тәҗе өзелмәсә, сөйрәп чыгара иде ул аны, – диде Барый, юаш кына.* А.Гыйләҗев. *Хәйрулла һәм Гани агайлар – күп йөргән юлчылар, тәртә сынса – тәртәне, тәҗе өзелсә, тәҗе бавын ялгап, ремонтлап куялар, һәм без, әллә ни тоткарланмыйча гына, юлыбызны дәвам итәбез.* А.Тимергалин

**ТӘҖЕЛ** *с. гар.* **1.** Бик тиз эшләнергә тиешле; ашыгыч. *Тегесенең шундый йомышы төшә, бусының тәҗел бер эше бар, нәтиҗәдә син иртәдән кичкә кадәр бөтереләсең, син дөньяга кирәк.* Н.Нәҗми. *Тәҗел эшләрен кичектереп, киләсе кунакларына отказ биреп, больницага ашыкты.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик ашыгыч рәвештә; тоткарлыксыз, тиз генә. *Кискечләрен, чүкечен башташ янына куеп, ул тәҗел генә өйгә керде, тәрәзә кашына кыстырган сорнаен алып чыкты.* Р.Батулла. *Бигрәк тә Рәхимҗан сөенде: Карганың дөмегүе аңа тәҗел кирәк, ул куян йөрәге белән яшәүдән гарык иде.* Н.Гыйматдинова

**ТӘҖЕЛӘ́Ү** *ф.* Арбага тәҗе тарттыру; тәҗе кую, тәҗе беркетү. *Тәҗеләү озакка сузылды*

**ТӘҖЕЛЕ** *с.* Үзенә тәҗе тарттырылган. *Тәҗеле арба*

**ТӘҖЕЛЕК** *с.* Тәҗе өчен яраклы, тәҗе өчен билгеләнгән. *Тәҗелек тимерчыбык*

**ТӘҖЕЛЛӘНҮ** *ф. к.* **тәҗелләү**. *Йөк ташучылар пароход эченнән, тәҗелләнеп, өч зур сыра мичкәсе тәгәрәтеп чыгардылар.* Г.Тавлин

**ТӘҖЕЛЛӘП** *рәв. диал.* Ашыгыч рәвештә, ашыга-ашыга, тиз генә. *[Солдат] «курыкмыйм, курыкмыйм» дип, тәҗелләп аягын киенә, ди.* Әкият. *Өйгә киттем тәҗелләп.* Я.Емельянов

**ТӘҖЕЛЛӘ́Ү** *ф.* Берәр кая ашыгу. *Аңлатма бирү кирәкми, Андрей Платонович тәҗелләмичә әйткән.* М.Хуҗин

**ТӘҖРИБӘ** *и. гар.* 1) Төрле эшчәнлек, хезмәт нәтиҗәсендә яки билгеле шартларда яшәү дәверендә тупланган аң-белем, күнекмәләр җыелмасы. *Иҗатта бөтен гомерең буена тупланган тәҗрибә нигез булып ята.* Ш.Галиев. *Инде утыз елдан артык, беркая*

*да китмичә, шушында эшли, зур тәҗрибә алды.* Р.Фәизов

2) Билгеле күренешне өйрәнү яки фәнни яктан тикшерү өчен, нәрсәне дә булса махсус шартларда күзәтү, сынау эше. *Ул вакытта бишәр мең татар яшәгән Мөслим, Үзбәгәрәк, Татар Караболагы авыллары атом зонасында тәҗрибә үткәрү өчен калдырыла.* Ф.Бәйрәмова. *Бөтенләй башка төрле җан иясе ул ---, тәҗрибә өчен лабораторияләрдә асрала торган күселәр, этләр кебек.* М.Маликова

3) Башлангыч, үрнәк дип карала алырлык, беренче үрнәк булган яки булырлык эш, хезмәт һәм шуның нәтиҗәсе. *Бу эшне беренче тәҗрибә рәвешендә Хисам, Гәрәй, Роберт, Мидхәт, Равил иптәшләрдән башларга кирәк.* Х.Туфан. *Бу жанр формасына хас югары стиль һәр урында да җитенкерәмәүгә, трагик хата булмау кебек якларына карамастан, аны трагедия жанры тудыру юлында бездәге беренче тәҗрибә дип әйтергә мөмкин.* А.Әхмәдуллин

4) Тормышны үз башыннан кичереп танып белүдән алынган сабак, дәрес. *Тарихта ялгышып юкка чыккан халыкларның ачы тәҗрибәсе дә, бүген алдынгылар сафында булган илләрнең яшәү рәвеше дә күренә.* Т.Миңнуллин. *Холкы шундыймы, әллә ачы тормыш тәҗрибәсе өйрәткәнме, Фәридә, урам тел бистәләре төсле, теләсә кем алдында ачылып китәчәк түгел.* Т.Галиуллин

**ТӘҖРИБӘ́ ИТҮ** *ф.* Берәр нәрсәнең, күренешнең асылына төшенү өчен, аны билгеле шартларда тикшерү, сынау. *Диван әһле егетне мизанга тартып, һөнәрен вә әдәбен тәҗрибә иттеләр.* К.Насыйри. *Мин үзем шушы өлкәдә тәҗрибә итеп бер кечкенә адым ясап караган идем: «Капкорсак патша» дигән бер әкият язган идем.* А.Алиш

**ТӘҖРИБӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **тәҗрибә итү**. *Әгәр, ни эшли, дип сорасалар, тәҗрибә кылып карый, дисеннәр.* Г.Камал. *Атабыз Адәм моңа каршы бер тәҗрибә кылып карауны кирәк тапты һәм шешәгә охшаган савыт алды, аңа үзенең орлыкларын койды да диңгезгә ташлады ---.* Ф.Яхин

**ТӘҖРИБӘЛЕ** *с.* 1) Нинди дә булса эш, һөнәр, өлкә һ.б.ш.ларда тәҗрибәсе (*1 мәгъ.*), белеме, күнекмәләре булган. *Яхшы билгеләр куелган таныклык алып кайткан 17 яшьлек үсмер кызны Иләбәрнең тәҗрибәле тракторчысы Хәбибулла абый Гариповка сукачы итеп билгелиләр.* Т.Нәҗмиев. *Ләкин Зәйнәп, тәҗрибәле табибә буларак, карчыкны кирәкмәс уйларыннан арындырырга, сүзне бөтенләй икенче якка борырга кирәклеген яхшы аңлады.* Х.Ибраһим

2) Зур тормыш тәҗрибәсенә ия булган. *Шунда тәҗрибәле үтә чая бер хатын: «Бу балакайны мәхәббәт сәламәтләндерде», – дигән иде.* М.Хәбибуллин. *Әхмәдиша абзыйның хаклыгына мөһер сугарга ашыкмаса да, тәҗрибәле, күзәтүчән кешенең сүзләрендә дөреслек орлыгының тамыр тибеп ятуы бәхәссез иде.* Т.Галиуллин

3) Күнеккән, гадәтләнгән, үз эшен яхшы башкара торган, үткен (күз-колак һ.б. тур.). *Тәҗрибәле күз бу авылның кайчандыр бик зур булуын һәм бик тыгыз утырганлыгын чамалар иде.* Ә.Еники. *Аның тәҗрибәле үткен күзләре күптән инде Гөлшәһидә белән Диләфрүзнең эчтән сызып яшәүләрен күрә иде.* Г.Әпсәләмов

**ТӘҖРИБӘЛЕЛЕК** *и.* Тәҗрибәле булу сыйфаты. *Каян килгән соң шагыйрьгә яшь авторлар белән эшләүдә тәҗрибәлелек, яшьләргә игътибарлы караш, итагатьлелек?* И.Юзеев. *Шагыйрәнең унҗиде-унсигез яшьлекләргә хас самими, омтылышлы иҗатында олыларга хас тәҗрибәлелек төсмерләнә.* Р.Харрасова

**ТӘҖРИБӘСЕЗ** *с.* 1) Нинди дә булса эшнең, шөгыльнең һ.б.ш.ның нечкәлекләрен белеп бетерми торган; шул эшкә, шөгыльгә һ.б.ш. кирәкле күнекмәләре булмаган. *Бүтән чакта бит югыйсә алар дәресне дә юньләп тыңламыйлар, күзләре гел яшь һәм тәҗрибәсез укытучыда, уйлары аңа карата тагын нинди этлек эшләү турында гына була торган иде...* З.Мифтахов. *Чынлыкта тәҗрибәсез табиблар хакындагы уй Миңниса өчен чит-ят планеталар кебек еракта иде.* Ф.Җамалетдинова

2) Тормыш тәҗрибәсе булмаган. *Яшь шул әле, тәҗрибәсез, күңелен биләгән шушы әрсез хиснең көнләшү икәнлеген уйлап та карамый!* А.Гыйләҗев. *Күрәсең, яшь Исхакый тормыш сәясәтендә алай ук тәҗрибәсез һәм наив булмагандыр...* А.Тимергалин

**ТӘҖРИБӘСЕЗЛЕК** *и.* Тәҗрибә булмау күренеше; тәҗрибәсез булу хәле. *Дөресен әйтергә кирәк, минем тәҗрибәсезлек тә, кышкы шартлар да – бары да безне җиңелүгә китерделәр.* А.Алиш. *Әй шушы беркатлы уйлар, тәҗрибәсезлек, яшьлеккә хас мин-минлек һәм күпбеләмлек бәласе!* Р.Низамиев

**ТӘҖРИБӘЧЕ** *и.* Тәҗрибәләр ясаучы, тәҗрибәләр ясарга яратучы кеше. *Роберт теоретик булса, Булат – тәҗрибәче.* Т.Әйди. *Һәрбер укытучы үз фәне буенча эзләнүче һәм тәҗрибәче булырга тиеш.* Мәгариф

**ТӘҖРИБӘЧЕЛЕК** *и.* Тәҗрибәләр үткәрү эше, тәҗрибә ясау шөгыле. *Бу елларда Яңгул урта мәктәбе балаларга хезмәт тәрбиясе бирү, тәҗрибәчелек эшен оештыру буенча район һәм республика күләмендә алдынгы мәктәпләрнең берсе булды.* Г.Мөхәммәтшин. *Казан, Мәскәү фәнни тикшеренү институты галимнәренең биреме буенча тәҗрибәчелек эшләре белән шөгыльләнәләр, умартачы һөнәренә өйрәнәләр.* Р.Баттал

**ТӘЗЕ́М КЫЛУ** *ф. к.* **тәгъзыйм кылу**. *И Идел-йорт, Идел-йорт, Идел эче имин йорт, Атам кияү булган йорт – Иелеп тәзем кылган йорт.* Дастан

**ТӘЗКИРӘ** *и. гар. кит.* 1) Истәлек, хатирә, ядкәр; сагынмалык. *Хәят абыстай беренче мәхбүбеннән тәзкирә уларак калмыш икенче мәхбүбеннән дә аерылды, хыялында ике мәхбүбнең фәкать сурәтләре калды.* З.Һади

2) *иск.* Рәсми документ; таныклык, паспорт. *Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан? Тәзкирәңә «мөслим» диеп игълан таккан?* Г.Тукай. *Габделмалик әйтте: – Әй олуг зат, сән безне ошбу шәһәр адәме итеп, --- бер тәзкирә алып бирсәң, мән сәңа биш мең алтын бирермен, – диде.* Ф.Халиди

**ТӘЙ** *и.* Ат, ишәк, дөя кебек йөк хайваннарының аркасына салынган йөкнең, куржынның бер ягы

**ТӘЙЯР** *с. гар. иск.* Әзер. *[Мәдрәсәнең] матди җәһәтләренә һәрвакыт тәйяр торучылар бигрәк мәрхүмә мөхтәрәмә Суфия бикә белән зәүҗе Сәлимгәрәй Җантурин була.* Ш.Бабич

**ТӘК** *рәв. рус сөйл.* **1.** 1) Бернинди эш белән шөгыльләнмичә, эшсез, буш. *Арадан икенчесе: – Җәмәгать, бездә «халык язучысы», «халык шагыйре» дигән исемнәр бар. Арада, лаеклысы янында, титулны тәк кенә эләктергән әрсезләре дә җитәрлек.* Т.Галиуллин. *Тәк йөрү. Тәк кенә басып тору*

2) Бернинди максатсыз, гадәттәгечә, уйламыйча гына (сөйләү, әйтү, эшләү, тору); болай гына, шулай, шушы рәвешле

3) Бушка, бер файдасызга. *[Мә], мулла, садака. Ике тиене хәердән, өч тиене тәк китсен...* Г.Бәширов

**2.** *ы. функ.* Берәр кеше белән сөйләшкәннән соң, уйга калып, аптырап торганда әйтелә; алай, менә-менә. *Тәк, тәк, дип әйтте, ди, тәкә башы казанга кергәч.* Әйтем. *Ул таза йодрыгын әле Шәяхмәт, әле Хәкимулланың авыз тирәсендә уйната башлады. – Әле сез шулай иттегезмени? Алай икән... Тәк, тәк... Моның өчен, беләсезме, нәрсә?* М.Мәһдиев. *– Тәк, – диде председатель йончыган тавыш белән.* Казан утлары

**ТӘКАТЬ** *и. гар.* 1) *кит.* Көч, куәт, егәр. *Зыя да, каршы барырга тәкате булмаганга, караңгы төннәрдә, --- көймәле извозчикны яллап, шуңа таба юнәлә иде.* Г.Ибраһимов

2) Чыдамлык, түземлелек, сабырлык. *Күтәргә тәкать булмау*

◊ **Тәкать кору** Түземлек бетү. *Иртән кыен, кичен кыен, Тәкать коргач, тот та сыз.* К.Нәҗми. *Күпертүләр гиперболага юл бирә башлагач, Р.Фәйзуллинның да тәкате корый.* Т.Галиуллин. **Тәкать тота алмау** Түземсезләнү, ашкыну. *Безнең милләт, мескен, шул вакытта йоклаганмы, ни эшләгәндер, мин ансын белмим, ләкин безнең милләт баягы иптәшләренең кисәктән генә болай ук югары китүләренә тәкать тота алмаган.* Г.Тукай. *Зыяны гүя яшен сукты. Ул, агулы хәбәрне укып бетәргә дә тәкать тота алмыйча, урыныннан сикереп торды.* Г.Ибраһимов. **Тәкатьне корыту** Борчу, түзмәс хәлгә җиткерү, теңкәгә тию. *[Шәкерт:] – Бизгәк кенә тәкатьне корыта, аны уздырып булса, эшләргә дә мөмкин булыр иде, – ди.* Ш.Камал. **Тәкатьтән тыш** Көч җитмәслек, хәлдән килмәслек. **Тәкатьтән язу** *к.* **тәкать калмау**. *Бервакыт тәмам инде тәкатьтән язгач, берәү әйтә моңар: «Бар, – ди, – фәлән җирдә --- тау тишегендә бер дәрвиш булыр, --- ул ни әйтер сиңа...»* Ш.Камал. **Тәкать тоту** Түзеп тору, чыдау. *Бу падишаһымызның заманында тәкать тотарлыгымыз калмады.* Р.Батулла

**ТӘКАТЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Түзә алмаслык, сабыр итәрлек булмаган, түзеп торгысыз, чыдап булгысыз (авырлык, авырту һ.б.ш. тур.). *Тәкатьсез сагыш ярсулы дәрт тулы көйгә кучте.* К.Нәҗми

2) Түзем булмаган, берәр авырлыкка чыдамаучан; түземлеге җитми торган. *Ул тарту мәсьәләсендә бигрәк тәкатьсез: тәмәкенең берсе артыннан икенчесен кабызып кына тора.* Н.Әхмәдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тыелгысыз рәвештә; түзмичә, түземсезләнеп, сабырсызланып. *Мәгъсум бичара яңадан казыйга керергә дә куркыр, тәкатьсез булып аулакка чыгып еглар иде.* З.Һади. *Мин комачтай кызарып киттем бугай, ә Сабира тәкатьсез шаркылдап көлеп җибәрде.* Ә.Еники

2) Бик нык, чиксез, каты; түзә алмаслык рәвештә. *Баш һаман тәкатьсез сызлый.* С.Җәлал. *Тәкатьсез рәвештә сусагач, краннан стаканга агызып, суның тәмен авызына якынайтканчы ук күзе белән тойгандагыча, Аит ул сүзләрне мәгънәсе аңына барып җиткәнче үк укып йотты.* Ә.Гаффар

**3.** *и. мәгъ.* Сабырсыз, түземлеген югалткан кеше. *Тәкатьсезнең үлеме дә вакытсыз.* Мәкаль

◊ **Тәкатьсез калу** Берәр нәрсәдән түземлекнең, чыдамлыкның соңгы чигенә җитү, сабырлыгын югалту. *Картның сакал-мыеклары тетри иде, тәкатьсез калган ерткыч шикелле ыңгырашты да: – Ләгънәт сиңа! Чык! Күземә күренмә! – диде.* Ш.Камал

**ТӘКАТЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Тәкатьсез хәлгә килү, тәкате бетү; түземсезлек, сабырсызлык күрсәтү. *Эчкән саен тагын берәр рюмка тотасы килеп тора. Мин артык тәкатьсезләнмимме, әй?* А.Хәсәнов. *Ул хатның һичшиксез киләсенә ышансам, бәлки, азрак дулкынланыр, бу кадәр тәкатьсезләнмәс идем.* Н.Әхмәдиев

**Тәкатьсезләнә бару** Торган саен ныграк тәкатьсезләнү

**Тәкатьсезләнә башлау** Тәкатьсезләнү билгеләре сизелү

**Тәкатьсезләнә төшү** Беркадәр тәкатьсезләнү; тагын да тәкатьсезләнү

**ТӘКАТЬСЕЗЛЕК** *и. кит.* Тәкатьсез булу үзлеге; түземсезлек, сабырсызлык. --- *җандагы әрнү көчәя генә. Аның белән түземсезлек, тәкатьсезлек тә көчәя.* М.Кәбиров. *Эш сәгате бетүен тәкатьсезлек белән көтеп ала.* Н.Габдуллина

**ТӘКӘ** *и.* 1) Сарык яки кәҗәнең иркәге. *Киң булып алга чыккан күкрәкләр, куе сакал, таза сыйраклар. Судан аңар гайрәтле дәү тәкә карап тора иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Җиде аршынлы бүрәнә белән китереп төртәләрмени: күтәрелеп карасам, теге, нәсел тәкәсе – меринос икән.* М.Мәһдиев

2) *диал.* Эченә бәрәңге, ит, ярма һ.б.ш. әйберләр салып пешерелә торган озынча бөккән. *– Тәкә пешеп өлгерер микән инде? – диде Вәзирә, иренең үзенә әйткән сүзләренә игътибар итмичә.* Р.Газетдин. *Бәрәңге тәкәсе пешеримме?* Р.Кәрами

3) *диал.* Бәрәңге. *Бакча тәкәсен пешерергә кирәк иптәшкә.* Г.Толымбай

4) *диал.* Суганның орлыклы башы. *Суганның тәкәсенә тимә, орлык өчен кирәк.* Сөйләм

5) *диал.* Су аша салынган корылманың таяну баганасы, терәге. *Күпер тәкәсе*

6) *куч.* Металл акчаның герб төшерелгән ягы; күн

◊ **Тәкә мөгезе** *дорфа* Берәр нәрсәне эшләргә яки бирергә җыенмау билгесе буларак, имән һәм урта бармак арасыннан баш бармакны чыгарып төйнәлгән йодрык; кәҗә тоягы, кукиш. *Кинәт ишеккә таба китте дә ярты юлда кире борылды, барысын шаккаттырып, әтисенең борын төбендә «тәкә мөгезе» уйнатып алды.* Г.Ахунов

**ТӘКӘАГАЧ** *и.* Утын кискәндә яки такта ярганда бүрәнә кую өчен гади җайланма, кузла

**ТӘКӘББЕР** *с. гар.* **1.** 1) Характерында үзен башкалардан өстен кую гадәте булган, үзен һавалы тоткан, эреләнүчән, масаючан. *Рәгыйдә югалды да, аның урынына тәкәббер һәм чибәр Хәмдия пәйда булды.* Ә.Баян. *Тәкәббер кешенең эчендә ачу, үч тупланучан.* Х.Камалов

2) Тәкәбберлек белдергән, өстенлек чагылдырган, масаюлы. *Юка чәчен шома итеп артка тараган гестапо офицеры майор Реммер, аерата бер тәкәббер төс алып, тезен тез өстенә салды да өстәлгә яны белән борылды.* Г.Әпсәләмов. *Миңа аның тәкәббер, таләпчән профиле күренә.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **тәкәбберлек**. *Ерак иде күңле тәкәббердән, үләр иде безне яратып.* М.Җәлил

2) Үзен башкалардан өстен куючы кеше. *Тәкәбберне тәкә сөзәр.* Мәкаль. *Оят-хурлык китерерлек гөнаһ кылма, Кеше сөймәс тәкәббер дә, кол да булма, Акыллылар киңәшенә колак сал да Үз намусың, вөҗданыңны күбрәк тыңла.* Т.Миңнуллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Эре кыяфәт белән, масаеп; тәкәбберлек белдереп. *Бик үк барып чыкмаса да, үзен кырыс вә тәкәббер тота; болай да җәелеп китте бүген, янәсе.* Т.Галиуллин. *Ул, миңа һич игътибар итмичә, тәкәббер генә атлап, дача йортлары арасыннан узды да яшь бер алмагачның сусыл ботагын шырт итеп сындырып алды.* Г.Сабитов

**ТӘКӘББЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Масаю, эреләнү, кәпрәю, үзен һавалы тоту, эре кылану, тәкәбберлек күрсәтү. *Тәкәбберләнә һәм гозеребезне кире кага икән, димәк, аңа каршы яу чабарга үзе үк нигез бирә.* В.Имамов. *– Мин, мин булырга тиеш идем бу урында... – дип тәкәбберләнде, юк-барны мыгырданды.* Ш.Шәйдуллин

2) Масаючан кешегә әйләнү, холкы тәкәббер булып китү. *Сугышлар күбәйсә, халык бәйдән ычкына. Җиңүчеләр күбәйсә, хакимнәр тәкәбберләнә.* М.Галиев. *Шулай шул ул: берәүләр үзләрен әллә нинди биеклекләргә ирешкән кебек хис итәләр, масаеп китәләр, тәкәбберләнәләр, дөньяның кендегенә әверелгәндәй итеп тоялар.* Ф.Яхин

**Тәкәбберләнә бару** Торган саен тәкәбберлегә арту. *Вахит үзенең тагын кешелегенә кайтуына, кешеләргә хас булганча тәкәбберләнә баруына төшенеп, кинәт туктап калды.* Г.Гыйльманов

**Тәкәбберләнә башлау** Тәкәбберләнергә тотыну. *– Туктале, тукта, кызым... Ну, Катюшенька... – диде Нурлыбикә, бер тәкәбберләнә башласа, әйткәнне тыңламаячагын алдан ук сизеп.* Г.Кашапов

**Тәкәбберләнеп йөрү** Һәрвакыт, гел тәкәбберләнү. *Мин мондый, мин шуны булдырдым дип тәкәбберләнеп йөрү дөрес түгел.* Шәһри Казан

**Тәкәбберләнеп китү** Соңгы вакытта кинәт тәкәбберләнү. *Ә тәкәбберләнеп киткән яшь кенәз аларга: «Үсеп исәйгәч, мин үзем Казан өстенә яу йөреячәкмен», – дип әтәчләнә һәм качкыннар алдында түшенә таккан алтын тәресен үбә-үбә вәгъдә-ант итә.* М.Хәбибуллин. *Шул ук вакытта әдип, тәкәбберләнеп китеп, мин-минләнеп, башкаларга акыл сату юлына басмый, гыйбрәтле якларны зиһененә ала.* З.Рәмиев

**Тәкәбберләнеп тору** Хәзерге вакытта тәкәбберләнү

**Тәкәбберләнеп утыру** *к.* **тәкәбберләнеп тору**. *Апайның: «Кертмәсәң дә җылап үлмәм әле!» – дигән сыман, сер бирмичә, үзенә күрә бер тәкәбберләнеп утыруымы?* Г.Бәширов. *Мең ел элек яшәгән кеше исемен атап тәкәбберләнеп утырма!* З.Хәким

**ТӘКӘББЕРЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Тәкәббер кешеләргә хас булганча, һавалы рәвештә, масаеп, эреләнеп. *Әле генә үзен тәкәбберләрчә тоткан, салкын, әрсез Сәлах кинәт шүрләгән көчек шикелле шыңшырга кереште.* Г.Әпсәләмов. *Тәкәбберләрчә яшәвемне дәвам иттем.* Сөембикә

**ТӘКӘББЕРЛЕК** *и.* Тәкәббер булу, эрелек, мин-минлек, масаючанлык. *Юк, элеккеге Борһанга хас тәкәбберлек һәм дорфалык белән ачуын белдереп ишекне --- япмады.* М.Хәсәнов. *Хатыннарның берсе, мисаллар китерә-китерә, хәзерге яшьләрнең тәкәбберлеген, ваемсызлыгын сүгеп алды.* С.Шәмси

**ТӘКӘ́ БОРЧАГЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан берьеллык үлән үсемлек; яшел массасы терлек азыгы буларак, орлыгы ризык итеп кулланыла торган культура; ногыт; *русчасы*: **нут бараний**. *Тәкә борчагының орлыкларын, җимешләрен азык буларак кулланалар.* Биология

**ТӘКӘДӘН** *и. диал.* 1) Уенның авыррак өлешләрендә катнаштырылмыйча гына уйнаучы кеше (гадәттә бала). *Син яшь әле, тәкәдән генә булырсың.* Ак юл. *Таяк тотышта иң аста калган малай тәкәдән («көтүче») була.* Р.Әхмәтьянов

2) *күч. шелт.* Авыррак эшләрдән читтә калучы

**ТӘКӘЛЕ** *и.* Берсе эченә икенчесе сызылган ике түгәрәккә басып, эчтәге түгәрәктәге уенчылардан берсенең түбәтәен алып качарга тырышудан гыйбарәт уен. *Балачакта тәкәле уен уйнарга ярата идек.* Безнең юл

**ТӘКӘЛЛЕФ** *и. гар.* 1) Төгәл шартларга, кагыйдәләргә нигезләнгән әдәплелек, нәзакәт. *Фатих Әмирхан Барудига килгән кунакларны каршы ала һәм сыйлый иде. Чөнки ул анда югары катлау арасында булган, тәкәллеф, йолагадәт һәм алар белән сөйләшү җаен белә иде.* М.Укмасый

2) Үзара мөнәсәбәтләрдә ясалма хөрмәт, риялы кыланыш, кыланчыклык. *Юк тәкәллеф, юк эрелек, утырасың син дә мин.* М.Гафури. *Мәҗлестә мөгаллимәләр, мөгаллимнәр, мәхәллә имамы, бай һәм аның әһалиясе бергә булалар, качу, тартыну, тәкәллеф кеби мәҗлеснең күркен, ямен китәрә торган кыланышлардан бу кичке мәҗлес пакь.* Г.Гыйззәтуллин

**ТӘКӘЛЛЕФЛӘНҮ** *ф.* Башкалар белән мөнәсәбәттә тәкәллеф саклау. *– Карале, Тимергали абый, – диде ул, артык тәкәллефләнмичә, – син нәрсә анда начальствога каршы пычак кайрыйсың?* А.Расих

**Тәкәллефләнә башлау** Тәкәллефләнергә тотыну

**Тәкәллефләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта тәкәллефләнү; һәрвакыт яки әледән-әле тәкәллефләнү. *[Әнигә:] – И Рабига, Рабига... Син дә картайган-*

*сың, – диләр... Авыл халкы тәкәллефләнеп тормый: ни бар, шуны әйтә.* М.Мәһдиев. *Әмма хәзер алай акны сорап, тәкәллефләнеп торыр чак түгел, үзенә очраган шушы бердәнбер адәм затын да ычкындырса, --- йокысы йокы булмаячак Шәрифнең.* В.Нуруллин

**ТӘКӘЛЛЕФЛЕ** *с.* **1.** 1) Әдәп кагыйдәләрен саклаучан, нәзакатле; кечелекле. *Әнә шул көннәрдә Гөлшәһидә күзенә ифрат игътибарлы һәм тәкәллефле Яңгура чалына.* Г.Әпсәләмов. *Шагыйрь үзе дә үтә тәкәллефле зат, нечкә психолог булып күз алдына баса.* Н.Хисамов

2) Зәвык белән эшләнгән, зәвыклы, матур. *Өйнең эче артык тәкәллефле булмаса да, җәй көннәрендә барча тәрәзәләреннән кояш нуры керер, эче яктырыр, күңелгә шатлык бирер иде.* З.Һади

3) Артык ясалма һәм риялы. --- *берсе үз-үзенә бик нык ышанган, бик тәкәллефле, горур, икенчесе шактый шома телле, тынгысыз, өлгер кешеләр иде.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тәкәллеф (*1 мәгъ.*) белән. *Өченчеләре исә, сүзнең бәһасен белеп кенә, тәкәллефле итеп, җәй белән сөйләшә.* Ә.Гадел. *Тартакиев исә үзенең гаепсезлеген һәм көчлелеген тоя иде, ул тәкәллефле елмаеп барды, бүтән сүз кайтармады.* Х.Камалов

2) Зәвыклы итеп, пөхтә, матур. *Ул өс-башын да шулай тәкәллефле тота.* Г.Ибраһимов

3) Ясалмалылык белән. --- *һәммәсе дә абруйлы-дәрәҗәлеләр, затлы киенгәннәр, үзләрен бик горур һәм тәкәллефле тоталар, һәм бу – Камилнең күңеленә бигрәк тә хуш килә, имеш.* Р.Мирхәйдәров

**ТӘКӘЛЛЕФЛЕЛЕК** *и.* Тәкәллефле булу, әдәплелек, нәзакәтлелек. *Тәкәллефлелек – бары әйбәт күренү өчен эшләнә торган ясалма гадәт, алдавыч бер нәрсә генә, дип карый иде ул.* Х.Камалов

**ТӘКӘЛЛЕФСЕЗ** *с.* **1.** 1) Үз-үзен тотышында артык иркен, тәкәллеф сакламаган, нәзакәтсез. *Безнең арабыздагы тәкәллефсез мөгамәлә, әйбәт юморга нигезләнгән шаян тәнкыйть, уен-көлке белән эчтәге тирән яраларны дәвалау – бер-береңнең күңелен күтәреп рухландырулар безне бер-беребезгә кирәкле шәхесләргә әйләндерде.* Н.Арсланов. *Хәер, төркиләрдә үз телләренә тәкәллефсез мөнәсәбәт ерак гасырлардан ук килә.* Татарстан яшьләре

2) Кыланусыз, гади; эчкерсез. *Гомумән, алар – бик ачык һәм тәкәллефсез кешеләр, гадәттә морза халкында була торган, морза булмаган кешеләргә ят һәм кызыксыз тоела торган хосусиятләр аларда күренми иде.* Гали Рәхим. *Авыл хатыннары белән сөйләшеп утырырга яратам мин. Алар тәкәллефсез була.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Тартынмыйча, уңайсызланмыйча, тәкәллеф сакламыйча, артык иркен. *Ул бер дә тәкәллефсез генә үзенең хаҗ җөббәсе белән вокзал идәненә килеп утырды.* М.Галәү. *Табын янында тын утыру шулай авыр тәэсир итсә, инде өстәл янында кунакларның үзләрен тәкәллефсез тотуы --- тагын да күңелсезрәк.* Татар халык ашлары

**ТӘКӘЛЛЕФСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Үзен артык иркен тоту, әдәп сакламау, тәрбиясезлек күрсәтү. *Мөслимә кебек: «Өйгә кайткач та туфрак бонитеты дип утырма әле», – дип тәкәллефсезләнмәс иде...* Н.Көбәш

**Тәкәллефсезләнә бару** Торган саен ныграк тәкәллефсезләнү

**Тәкәллефсезләнеп китү** Кинәт тәкәллефсезлек күрсәтү

**Тәкәллефсезләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта тәкәллефсезләнү

**ТӘКӘЛЛЕФСЕЗЛЕК** *и.* Үз-үзен тотышындагы нәзакәтсезлек, артык гадилек; тәртипсезлек, тәрбиясезлек. *Әмма Гамил Афзалның сатира стиленә тәкәллефсезлек, дорфалык гомумән хас түгел.* Н.Хисамов. *Мондый тәкәллефсезлеккә исе киткән кыз һушын җуйды.* Идел

**ТӘКӘ́ МАҢГАЕ** *и.* Тауның бозлык шомарткан сөзәк ягы; бозлык шомарткан кыя. *Карелиядә тәкә маңгайларын еш очратырга була*

**ТӘКӘМӨГЕЗ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан басу һәм юл буйларында, чокырларда биек булып үсә торган баллы үсемлек; *русчасы:* **донник**. *Бер гектар тәкәмөгез басуы 300–800 кг хуш исле ак төстәге бик тәмле бал бирергә мөмкин.* Ф.Дәүлиев. *Тәкәмөгезнең барлык төрләре дә күп микъдарда хайваннар өчен агулы һәм зарарлы үсемлек буларак билгеле.* Агулы үсемлекләр

**ТӘКӘ-МӨКӘ** *и. диал.* Әкәм-төкәм. *Тәкә-мөкә, мөгезең чыгар, Сыер бирәм, ат бирәм.* Такмак

**ТӘКӘРЛЕК** *и.* 1) Шөлдисыманнар отрядыннан башындагы йоны мөгез кебек кабарып торган озын сыйраклы күчмә саз кошы; бибек; *русчасы:* **пигалица**. *Тәкәрлек болын һәм сазлыкларда, кырларда һәм көтүлекләрдә оялый.* Биология. *Кайдадыр тартар кычкыра, тәкәрлекләр елый.* Казан утлары

2) Биткә, тәнгә чыга торган тап, сипкел. *Йөзен күгәрчен күкәе белән рәттән куярлык бар: аны эреле-ваклы тәкәрлек басып киткән.* В.Имамов

3) *күч.* Бик сипкелле кеше. *Җиккән ат чабамыни? Ул юырта гына. Шуны да белмисең, тәкәрлек!* Ф.Абдуллин

◊ **Тәкәрлек йомыркасы** Бите сипкелле булган кеше турында. **Тәкәрлек күкәе** *к.* **тәкәрлек йомыркасы**. *Әй син, тәкәрлек күкәе! Юлыма аркылы төшсәң, ни буласын чамалыйсыңмы?* А.Гыйләҗев. **Тәкәрлек йомыркасы (күкәе) кебек** 1) Сипкелле. *Тәкәрлек күкәе төсле чуп-чуар битле, елтыр күзле, тәбәнәк кенә буйлы бер йомры кыз белән кинода танышып, караңгыда кулын кысып утырдым.* Казан утлары; 2) Артык чуар

**ТӘКӘРЛЕКЛЕ** *с.* 1) Тәкәрлекләре булган; тәкәрлекләр тереклек иткән. *Айдар, түмгәкләргә сөртенә-сөртенә, тәкәрлекле болын буйлап авылына таба йөгерде.* Р.Бәшәр. *[Ул көй –] Тилгән тавындагы арыш кыры, тәкәрлекле күл камышы шаулавы ул.* Ә.Гаффар

2) *күч. диал.* Сипкелле, сипкел төшкән. *Тора-бара гыйшык бетте, яратмадым: тәкәрлекле...* Г.Афзал

**ТӘКӘРЛЕ́К-МӨКӘРЛЕК** *и. сөйл. к.* **тәкә-мөкә**

**ТӘКӘ́ САКАЛЫ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан буяу алу өчен чимал буларак файдаланыла торган сары чәчәкле икееллык үлән үсемлек; *русчасы:* **вайда красильная**

**ТӘКӘ́ СӨЗЕШТЕРҮ** *и. этн.* Халык театры уеннарыннан берсе

**ТӘКӘ́ ЧАНА** *и.* Бүрәнә ташыганда, бүрәнә очы җирдән сөйрәлмәсен өчен, төп чана артыннан бераз ара калдырып тагылган кечерәк чана. *Төп чана артыннан кечерәк тәкә чана куялар да бүрәнәнең сөйрәлергә тиешле очын шул кечерәк чанага салып бәйлиләр.* Н.Фәттах

**ТӘКБИР** *и. гар.* Мөселманнарда «Аллаһу әкбәр» – «Аллаһ иң бөек» дип, Аллаһны олылау сүзе. *Һәр тарафтан тәкбир тавышлары ишетелә башлады.* Г.Камал. *Бер тапкыр, аларны «юнкерс»лар бомбага тотканда, ул блиндаж буенча тәкбир әйтеп йөргән иде.* Х.Камалов. *Бас тавышлы Сәгъдетдин абзый тагын тәкбир башлый, тагын салкын урамга йөзләгән бугаздан чыккан шау тарала.* М.Мәһдиев

◊ **Тәкбиргә тәкбир – садака** *иск. кит.* Берәр кешегә мөнәсәбәт аның үзенең мөгамәләсенә карата күрсәтелү: яхшылыкка – яхшылык, яманлыкка яманлык белән кайтарылу турында

**ТӘКЕ** *бәйл. диал.* Кадәр, чаклы, хәтле. *Иртәдән кичкә тәке яңгыр яуды*

**ТӘКЕЛДӘВЕК** *с. сөйл.* Күп тәкелдәүчән, сөйләшергә яратучан, телдәр, такылдык, бытылдык. *Тәкелдәвек бала*

**ТӘКЕЛДӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **такылдау**. *Ул турыда соңыннан бер җәелеп тәкелдәрбез әле.* К.Нәҗми. *Күрәкләрне өстерәп зираттан чыкканда ук Заһри кода тәкелдәп кайтты: – Карт кода кемгә генә әйтеп калдыра икән инде?* М.Мәһдиев

**Тәкелдәп алу** Бераз гына тәкелдәү

**Тәкелдәп тору** Һәрдаим, гел тәкелдәү

**Тәкелди башлау** Тәкелдәргә тотыну. *Светлана Фатыйманы кочаклап тәкелди башлады.* Г.Минский

**ТӘКЕЛДӘШҮ** *ф. сөйл.* Күп кеше бердән такылдау, сөйләшү

**Тәкелдәшеп алу** Кыска вакыт эчендә тәкелдәшү

**ТӘКЕЛДЕК** *с. сөйл. к.* **такылдык**

**ТӘКЕ́Л-ТӘКЕЛ** *иярт.* Сәгать йөргәндә, каты нәрсә белән каты нәрсәгә билгеле бер тактка бәргәндә чыга торган ритмик, саңгырау тавышны белдерә. *Өйгә керсәң, тәкел-тәкел, такыл-токыл сәгать йөргән тавыш кына.* С.Баттал

**ТӘКЕНҮ** *ф. диал.* 1) Абыну, сөртенү. *Тәрбияле, әдәпле күршесе, контейнерга барып җиткәнче, шул корыган алмагач ботагына тәкенеп егылуына, чүпчарның урамга, аяк астына чәчелүенә, чистартучыларга эшләргә җайсыз булуына төкереп тә бирми ул!..* Йолдыз

2) *күч.* Тап булу, туры килү, эләгү. *Сирәк-мирәк мондый хикмәт-әкәмәтләргә кайбер пыркарурлар тәкенеп, җентекләбрәк карарга омтылалар омтылуын.* Ватаным Татарстан

**Тәкенеп кую** Көтмәгәндә тәкенү

**ТӘ́КИ** *терк. рус сөйл.* Шулай да, бернигә дә карамастан, барыбер. *[Әти:] – Бар, хәзер үк хәлфәңә илтеп бир! --- Мин иртәгә дип тә карадым, әти тәки илттерде.* Г.Гобәй. *Күпме көтсә дә көтте, тәки туры китереп, чакырып кертте тегене.* В.Нуруллин

**ТӘКИЯ** *и. гар. тар.* 1) Суфи дәрвишләрнең яшәү урыны, уку, гыйбадәт кылу, зикер итү өчен шартлары булган бина. *«Тәкиядә утырган риялы суфиларның хәлләре ни кыяфәттә?» – диделәр.* К.Насыйри

2) Мәккәгә хаҗга килүчеләр өчен төзелгән кунакханә

3) Кабер өстенә, гадәттә танылган шәхесләр җирләнгән кабергә төзелгән төрбә; мавзолей. *Хуш, нәрсә соң ул тәкия? Үзебезнең телдә моңа туры килгән «төрбә» сүзен беләм, мәгәр «тәкия»не беренче ишетүем.* Ә.Еники. *Касыйм шәһәрендәге Шаһгали хан тәкиясе*

**ТӘККӘ** I *и. гар. тар. к.* **тәкия**

**ТӘККӘ** II *рәв. сөйл.* Максатсыз, кирәкмәгәнгә, мәгънәсезгә, болай гына, бушка, юкка, тиккә. *Эч поша! Гомерем бигрәк тәккә, бушка үтә.* Ш.Бабич. *Туган көн дигән булып тәккә акча түгәргә димәгән.* Р.Батулла

**ТӘКЛИФ** *и. гар.* 1) Тәкъдим. *Аш вә чәй җыелып алынганнан соң, Сабирның тәклифе буенча, учитель Зариф үзенең өеннән скрипкасын алдырды.* Г.Ибраһимов. *Минем тәклифем буенча, остазына каршы каты тел әйткән өчен, менә дигән зирәк, үткен егетләр мәдрәсәдән куылдылар.* Мирас

2) Боерык, әмер, йөкләмә. *Сабир боларның берен дә булдыра алмый, яратмый гына түгел, --- болар аңа авыр бер тәклиф, зур мәшәкать кебек тоелалар.* Г.Ибраһимов

**ТӘКЛИ́Ф ИТҮ** *ф.* 1) Тәкъдим итү; тәкъдим ясау. *Хөсәен әфәнде үз тарафыннан билгеле бер програм тәклиф итмичә, фикер эшләтер өчен юллар гына күрсәтә.* Г.Исхакый

2) Мәҗбүр итү, көчләп кушу, өстенә йөкләү. *Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр: «Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит!» – диләр.* Г.Тукай. *Мән җавап бирдем: – Шаһлан канунында буйлә юкдыр бер шаһ икенче шаһның адәмене мәзһәбкә тәклиф итәргә.* Ф.Халиди

**ТӘКЛИ́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **тәклиф итү**. *Гомерендә бер мәртәбә кыр хезмәтендә булмаган кызны чабата киенеп кырга барырга тәклиф кылулары бик аяныч хәлләрдән иде.* З.Һади

**ТӘКМӘРЛӘТҮ** *ф. диал. к.* **тәгәрәтү**

**ТӘКМӘЧ** *и. диал.* Мәтәлчек

◊ **Тәкмәч ату** Баш аша әйләнү, мәтәлчек ату. *Бала тәкмәч атып уйный*

**ТӘКМӘЧЛӘТҮ** *ф. диал.* Тәкмәчләргә мәҗбүр итү

**Тәкмәчләтеп алу** Тиз генә тәкмәчләтү

**Тәкмәчләтеп җибәрү** Тиз генә, кинәт кенә тәкмәчләтү

**ТӘКМӘЧЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Баш аша әйләнү, мәтәлчек ату. *Тәкмәчләп уйнау*

2) Торган җирдән, урыннан аву, мәтәлеп китү. *Тау төшкәндә тәкмәчләү*

**Тәкмәчләп китү** Кинәт яки тиз генә тәкмәчләү. *Малай, офицер өченче тапкыр атканнан соң, башы белән егылып тәкмәчләп үк китте.* Ф.Кәрим

**ТӘКРАР** *и. гар.* **1.** Кабатлау процессы, кабатлану күренеше. *[Бәдеркәй:] Җавапларым да шул вакыттагы җаваплар, тәкрарга хаҗәт юк, башка сүзләремезне үзеңезне күргәч сөйләшермез.* З.Һади

**2.** *рәв. мәгъ.* Кабат, кабаттан, яңадан, тагын. --- *күз көнендә тәкрар килү уе белән кире кайтып китәргә уйладым.* М.Гафури. *1904 нче елның язында да казах арасына чыктым. Көзендә тәкрар мәдрәсәгә килеп, фатирда тордым.* Мирас

**ТӘКРА́Р ӘЙЛӘҮ** *ф. иск. к.* **тәкрарлау**. *Таң беленгәч, Бәхтегәрәй кайтып китте. Хәлифә дә: «Иртәгә кич кил!» – диярәк тәкрар әйләде.* З.Һади

**ТӘКРА́Р ИТҮ** *ф. к.* **тәкрарлау**. *Анасының бер тәүлектән бирле тәкрар иткән шушы «килмәдеме?» сөальләре аның күңелендә әллә нинди тирән һәм иске җәрәхәтләрен яңадан ача иде.* Ш.Камал. *Ул арада хезмәтче егет килеп җитте. Ул да теге хатынның сүзләрен тәкрар итеп, мәсьәләне бик тиз кисте.* М.Гафури

**ТӘКРА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тәкрарлау**. *Бу укытуга Вәлид хәзрәт тә тәхсин итеп: «Сабакны бер хәреф алып, мең мәртәбә тәкрар кыйлырга кирәк», – диеп, балаларны нәсыйхәт кыйла иде.* З.Һади

**ТӘКРАРЛАНУ** *ф.* Кабатлану. *Бер хикәя вә анекдотның әллә ничәшәр мәртәбә тәкрарлануы да безнең ихласны кайтармый, тыңлаган саен тансык тоела иде.* Ш.Камал. *Я Алла, тарих тәкрарлана бит, дим.* Ф.Әмирхан

**Тәкрарлана тору** Әледән-әле тәкрарлану. --- *инде күптән зур шагыйрь дип танылган Нажар Нәҗми белән Казан, юк, бөтен татар халкы арасында иң тыгыз мөнәсәбәт урнашты; бу мәхәббәт һәр ике яктан да тәкрарлана, өр-яңа әсәрләрдә кабатлана торды.* Милли җаным

**Тәкрарланып килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә тәкрарлану. --- *җәмәгатьчелек фикеренең кирәкле булуы гел генә тәкрарлана килсә дә, гамәлдә рәсми идеяләр илдә бер генә кешенең фикеренә нигезләнә.* Кызыл таң

**Тәкрарланып тору** Гел, һәрдаим тәкрарлану; хәзерге моментта тәкрарлану. --- *«илдәге барлык милләтләр тигез хокуклы» дип тәкрарланып торуга карамастан, милли мәктәпләрнең әкренләп ябылуы, милли югары уку йортларының күпчелек төбәкләрдә ачылмавы моңа мисал була ала.* Ватаным Татарстан

**ТӘКРАРЛА́У** *ф.* Берәр сүзне, тәгъбирне кабатлау, кат-кат әйтү. *Ә аның белән бергә килеп чыккан Ногман абзыйның үз тугызы тугыз иде. Ул һаман бер үк нәрсәне тәкрарлый.* М.Хәсәнов. *Беляев белән Садыйковны берничек тә уртак фикергә китертеп булмый, һәркайсы үзенекен тәкрарлый…* Я.Шәфыйков

**Тәкрарлап бирү** Кем өчендер махсус тәкрарлау. *Сәеткә тәэсирне көчәйтү нияте белән җентекләп, тәфсилләп тәкрарлап бирүне кирәк тапты: – Битен куе каннан торган боламык иткәннәр.* Т.Галиуллин

**Тәкрарлап йөрү** Гел, еш, һәрвакыт тәкрарлау. *Әнисе эченнән генә: «Бара күр, балакаем, – дип тәкрарлап йөрде, – ул да көтә торгандыр, бар, күр, ахырлары хәерле булсын, раббым!»* К.Тимбикова. *Кагыйдәләр ятлаган да шуларны тәкрарлап йөри.* М.Маликова

**Тәкрарлап килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә тәкрарлау. *Рус тарихчылары, Алтын Урда – сугышчан, агрессив дәүләт, дип тәкрарлап килгәндә, ул китаптан без анда яшәгән халыкларның, бигрәк тә төрки халыкларның, алга киткән мәдәнияте, әдәбияты булуы турында исбатлауларны күрдек.* Н.Кәримова. *Ә бит чын педагоглар әллә кайчан тәкрарлап киләләр: сәләтсез бала юк.* Мәгариф

**Тәкрарлап кую** Тагын бер мәртәбә тәкрарлау. --- *яраның чыннан да Чечняда алынган булуын тәкрарлап куя.* Ф.Яхин

**Тәкрарлап тору** Гел, һәрдаим тәкрарлау; хәзерге моментта тәкрарлау. *«Базардагы көрәштә бер зәнҗи малаен егып алдым», – дип тәкрарлап тик тора.* В.Имамов. *Телевизор ачсаң, туктаусыз, сак, сизгер булыгыз, шикле кешеләрдән, шикле әйберләрдән саклагыз, дип тәкрарлап кына торалар.* Ә.Хәсәнов

**Тәкрарлап утыру** *к.* **тәкрарлап тору**. *«Зуррак бәлаләрдән аралый күр безне, и Ходаем!» – дип, эченнән генә туктаусыз тәкрарлап утыруга күчкән иде.* В.Имамов

**Тәкрарлап үтү** Сүз уңаеннан, башка фикерләр арасында тәкрарлау. *Яки берсе язганны икенчесе тәкрарлап кына үтә.* Һ.Такташ

**Тәкрарлап чыгу** Барысын да, рәттән, башыннан ахырына кадәр тәкрарлау. *Бер ел тулыр-тулмас бер арада Коръәнне ятлап кына түгел, тәкрарлап та чыга.* Г.Ибраһимов

**Тәкрарлый бирү** Бернигә дә карамый тәкрарлауны дәвам итү. *Борһан үзенекен тәкрарлый бирде: – Китәм!.. Улым гына кайтсын.* М.Хәсәнов

**ТӘКЪВА** *и. гар.* **1.** 1) Аллаһтан курку, гөнаһка керүдән саклану. *Бәс, синңа лаек түгелдер ки, мөрәүвәтне вә инсафны куеп, тәкъва юлыннан ерак булып, бу хәлдә шаһзадәне һәлак итәсең.* К.Насыйри

2) Чын күңелдән дингә бирелгән кеше, гөнаһ кылырга курыккан, диндар кеше. *Тәкъва – Аллаһ юлында ихласлык белән хезмәт итүче, дин кушканнарны гына үтәүче.* Р.Сафин

**2.** *с. мәгъ. к.* **тәкъвалы**. *Ишан чыккан турга иң тәкъва мәчет картлары, бил бөгеп, кул баглап, зекер әйтеп тордылар.* Г.Гобәй. *Вөҗданыннан шайтан кебек качып, Хакыйкатьне яшерүчеләр, Эчтән динсез, тыштан тәкъва булып, Хаклык сөйгән булып йөрүчеләр ---.* Р.Сәйфетдинов

**ТӘКЪВАЛАНУ** *ф.* 1) Тәкъвалыга әверелү, тәкъвалы булып китү

2) *күч.* Тәкъвалы булып кылану; тәкъвалы кеше кебек сөйләшү, эш итү һ.б.

**Тәкъвалана башлау** Тәкъвалануга табан үзгәрү

**Тәкъвалана төшү** Бераз тәкъвалану; тагын да ныграк тәкъвалану

**Тәкъваланып йөрү** Озак вакытлар, күптәннән тәкъвалану

**Тәкъваланып китү** Билгеле моменттан алып сизелерлек тәкъвалану. *Чөнки бик тәкъваланып китте: йорт эшеннән ваз кичеп, намаз-нияз дигән булып йөри башлады.* М.Мәһдиев. *Хәзер күбебез ярыйсы гына тәкъваланып киттек.* Татарстан яшьләре

**ТӘКЪВАЛЫ** *с.* Чын күңелдән дингә бирелгән, гөнаһтан сакланган, Аллаһның тыйганнарыннан тыелып, әмерләрен үтәп барган. *Ихтыяр көче нык булса, тәкъвалы булсак, безнең яныбызга бернинди дә җен-пәриләр, шайтан үзе дә килә алмас.* Безнең гәҗит

**ТӘКЪВАЛЫК** *и.* Тәкъвалы булу сыйфаты. *Җомагыл хәзрәтнең мөритләре: «Без дөньяны ташладык, тәкъвалыкны ихтыяр кылдык, Хода ризыкны ирешдерер, --- ризык бу көнлек булса, иртә өчен ишәк кайгырган», – дип, кәсепкә тырышкан адәмнәрне карун кеби дип хәкарәт кылалар иде.* З.Һади.

*И Раббым, миңа туры юл һәм тәкъвалык, күңел сафлыгы һәм үземдә бөтен кирәк нәрсәнең җитәрлек булуын бүләк итсәң иде!* Мең дә бер хәдис

◊ **Тәкъвалык сату** Чын күңелдән ышанмаган көе үтә дә дини, әхлаклы, шәригатьчә яшәгән булып кылану. *[Рокыя:] Үзе әткәй алдында чын рузалы булып, тәкъвалык сатып йөри.* Ф.Әмирхан

**ТӘКЪДИМ** *и. гар.* 1) Берәр мәсьәләне хәл итү, берәр эшне башкару рәвеше турында кемнеңдер тарафыннан башкалар карамагына куелган фикер һ.б. *Вафа өчен Сабирҗан тәкъдиме кулайрак иде.* М.Галәү. *Хәзер ул искиткеч кыю, шул ук вакытта кызыклы гына тәкъдимнәр кертә.* М.Хәсәнов

2) Берәр эштә катнашырга яки шул эш белән шөгыльләнергә өндәү, киңәш. *Әле генә бик эшлекле кыяфәттә бәрәңге алып кайтырга тәкъдим керткән Әлтафи инде аягүрә бастырып куелган иде.* М.Мәһдиев

3) Билгеле бер эшне үтәргә боерык, әмер, рәсми күрсәтмә. *Мөхәммәт, бүреген угалап, --- тәрәзәдән карап торган булып, баш мөхәррир Равил Фәйзуллиннан тәкъдим көтә.* Т.Галиуллин. *– Исәнбәт иптәш, сезнең әсәрдә Түләк уңай герой итеп бирелгән. --- Сезгә аны ярлы итеп күрсәтергә кирәк булыр, – дигән тәкъдим ясала.* Мирас

4) Ир-атның хатын-кызны үзенә кияүгә чыгуны сорап мөрәҗәгать итүе. *Икенче уку елы тәмамланып, имтиханнар тапшырылып беткәч, Әнвәр кызга тәкъдим ясады: – Хатыным бул! – диде ул, Дулкыниянең күзенә карап.* Г.Бәйрәмова

5) *икът.* Потенциаль сатып алучыга, кулланучыга дип ачык базарга чыгарылган товар яки хезмәт. *Ихтыяҗ һәм тәкъдим*

**ТӘКЪДИ́М ИТҮ** *ф.* 1) Берәр мәсьәләдә чишелеш юлын күрсәтү, киңәш бирү. *– Әйбәт хирург булачак, – диделәр өлкән хирурглар, һәм кафедра аңа аспирантурада калырга тәкъдим итте.* Г.Әпсәләмов. *Ашлы әмире берничә мәртәбә урыс кенәзләренә солых төзергә тәкъдим иткән.* Мирас

2) Берәр нәрсәне кемгә дә булса бирергә теләү; күрсәтү, сону. *Мин ашыкмыйча гына көмеш портсигарымны ачып, Бүләк Гаделовичка сигарет тәкъдим иттем, үзем дә берне алып кабыздым.* Г.Афзал. *Кәшифә малае бер яртыга да риза. Аңа акча тәкъдим итеп тә тормыйлар.* И.Нәбиуллина

3) Берәр нәрсәне сынап карарга, сатарга теләк белдерү, шул әйберне күрсәтү. *Ә Яңгура тәкъдим итә торган аппарат, исеме яңа булса да, медицинада күптән билгеле нәрсә.* Г.Әпсәләмов

4) Берәр нәрсәне үтәргә кушу, боеру, күрсәтмә бирү. *Райком кәгазе кырдагы колхозчыларга бу шатлыклы хәбәрне җиткерергә тәкъдим итә иде.* Казан утлары

5) Берәр урынга билгеләргә, берәр оешмага сайларга һ.б.ш. өчен кемнең дә булса исемен күрсәтү. *Әдип Маликович, пенсиягә китәр вакыты җиткәч, министрлыкта минем кандидатураны тәкъдим иткән: институтны да, фәнне дә яхшы белә, алга җибәрә торган, перспективалы иптәш дип.* Г.Бәйрәмова

6) Хезмәттәге уңышлар, мактаулы эшләр өчен берәр кешене бүләкләүгә кую. *Доктор Шәфкатияне биология буенча иң күренекле Нобель премиясенә тәкъдим иттеләр.* А.Тимергалин

7) Берәү белән таныштыру, шуңа игътибарны юнәлтү теләге белән аның кемлеген әйтү, аерып күрсәтү. *Нурислам хаҗи кулын аның җилкәсенә салып: «Менә сезгә хәлфә абый...» – дип безгә тәкъдим иткәндә дә, аның йөзенә кызыллык чыкмады.* Г.Гобәй. *Ул инде тәкъдим итә торган кәләшенең уңганлыгын, яшьлеген, сылу булуын сөйләп китте.* М.Хәсәнов

8) Нинди дә булса хис, фикерне берәр төрле чара белән белдерү, сиздерү. *[Егет:] Мәхәббәт тә шул дәрәҗәдә кадерле миңа. Мин әнә шул кадерле мәхәббәтемне сезгә тәкъдим итәм.* Г.Галиев

**ТӘКЪДИМНАМӘ** *и. гар.-фар.* Берәр рәсми оешмага юллана торган тәкъдим язуы. *Бүгенге түрдәгеләргә Мәдхияләр көйлибез, Тәкъдимнамә тутырабыз.* К.Булатова

**ТӘКЪДИ́М ЯСАУ** *ф.* 1) Үзенә хатынлыкка чыгарга сорау (ир-ат тур.). *Ике ел дуслашып йөрдек. Ул миңа тәкъдим дә ясады, ә мин аңа, укып бетергәнче, дип әйтә килдем.* Г.Әпсәләмов. *Әйе, оныта язганмын, шулай да бар иде бер кыз. Мин аңарга тәкъдим дә ясаган идем хәтта.* Р.Мөхәммәдиев

2) *к.* **тәкъдим итү** (*1 мәгъ.*). *Институтны тәмамлагач та, --- атаклы профессор Казембек үзе аңа Казанда ординатурада калырга тәкъдим ясаган, ә Әбүзәр абзый авылга җибәрүләрен үтенгән.* Г.Әпсәләмов

**ТӘКЪДИР** *и. гар.* 1) *дини* Аллаһы Тәгаләнең булган һәм булачак һәрнәрсәнең, туачак һәркемнең үткәнен һәм киләчәген, алдан белеп, үзгәрмәслек итеп Ләүхелмәхфузга язып куюы; язмыш. *Тәкъдир – булмастан борын булачак нәрсәнең булуын тәгаен кылып кую димәкдер.* Р.Фәхретдин. *Әгәр дә мужиклардан: «Балабыз ничә ел укыды, бернәрсә дә белмәде», – дип әйтүчеләр улса, Вәлид хәзрәт: «Хода тәкъдире, тәкъдирдән узып улмый шул», – диеп, ни булган гаепне Аллаһы тәбарәкә вә тәгаләгә йөкләп котыла иде.* З.Һади

2) *дини* Ләүхелмәхфузга алдан язып куелган вакыйгаларның, хәлләрнең, вакыты җитеп, гамәлгә ашуы, барлыкка килүе, булуы. *Дустым вә шәригем мулла Габдулла хәзрәткә дога вә сәлам бәгъдендә, тәкъдире илаһи ирешеп, кече кызым Гаишәне шәкертегез Сабир хаҗига никахландырмыш идек.* Г.Камал

3) Әҗәл, үлем. *Син ташласаң да, мин ташламам, Тәкъдирләрем җитеп үлмәсәм.* Җыр. *[Азымбай:] Яшьлек тамырыбыз Байтүрә каты наукасланып, тәкъдирем җитте дип, әҗәл көтеп ятыр.* Г.Ибраһимов

4) *иск.* Бәя бирү, бәя билгеләү. *Мин малорус әдәбиятын, Шевченко шигырьләрен аңлый алсам да, әдәби тәкъдиренә керә алмыйм.* Г.Ибраһимов

5) Уңай бәя, ихтирам. *Ниһаять, Р.Мәрдановның үзеннән элек иҗат иткән авторларның хезмәтләренә карата игътибарлы булуы да тәкъдиргә лаек.* М.Госманов

6) Нәрсәнең дә булса алдагы яшәеше, киләчәге, күрәчәге. *Ил тәкъдире ил өстендә.* Мәкаль

7) Нәрсәнең дә булса алдагы хәле, яшәү-яшәмәү мәсьәләсе. *Шәһәрдәге*

*кызыл гаскәрнең тәкъдире турында бер сүз дә юк. Ихтимал, бөтен килеш кырылып беткәннәрдер.* Ш.Усманов

◊ **Тәкъдир дәфтәре** *дини к.* **тәкъдир тактасы**. *Ни кызганыч, 1886 елның 29 августы Бибимәмдүдәнең тәкъдир дәфтәренә язылган бәхетле көннәрнең соңгысы булган икән.* М.Әмирханов. **Тәкъдир тактасы** *дини* Кемнең кем булып кайчан туасы, ни күреп кайчан үләсе Аллаһы Тәгалә тарафыннан алдан язылган такта; Ләүхелмәхфуз. *Шагыйрьләрнең һәммәсе дә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дән генә чыгарга тиеш дип, тәкъдир тактасына язылмагандыр бит.* З.Бәшири

**ТӘКЪДИРДӘ** *терк.* Очракта, хәлдә. *Бухгалтер аның сүзен яратмаган рәвештә: – Юк бит, балык булмаган тәкъдирдә дә, алар һичнәрсә югалтмыйлар.* Ш.Камал. *Иҗатларын таныган тәкъдирдә дә, җибәргән хаталары өчен К.Тинчурин, Г.Камалларга да зыялылар киштәсендә урын табылмый.* Т.Галиуллин

**ТӘКЪДИ́Р ИТҮ** *ф.* 1) *дини* Алдан билгеләү, язу (Аллаһы Тәгалә тур.). *Сине Аллаһы Тәгалә тәкъдир итеп татар милләтендә яраткан икән, телеңне сөй, тарихыңны өйрән, башка милләтләрне хөрмәт ит – бу мөселманның сыйфаты.* Безнең гәҗит

2) Берәүнең эшләгән эшен тану; уңай бәя бирү. *Чыкты, ахры, бездән дә бербөтен кеше: Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше.* Г.Тукай. *Агымдагы тәнкыйтьтә хәзер комплиментарлык, чама белмичә мактау рухы өстенлек итә. Бу бигрәк тә «син – миңа, мин – сиңа» принцибыннан чыгып язылган, бер-берсен мактауга, тәкъдир итүгә корылган язучылар тәнкыйтендә өстенлек итә.* Т.Галиуллин

3) Ихтирам итү, кадерле күрү. *Ләкин адәм --- хәссас күңел белән яратылсын – әнә шулар гына Мәрьямне тәкъдир итәр, шулар гына аны аңлар.* Г.Ибраһимов. *Шуның өчен дә Мансуров аны тәкъдир итә.* Г.Бәширов

**ТӘКЪДИ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тәкъдир итү**. *Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне һәм һәрбер эшне алдан ук тәкъдир кылган.* Ә.Максуди

**ТӘКЪДИРЛӘ́Ү** *ф. к.* **тәкъдир итү** (*2, 3 мәгъ*). *Күрсәткән хезмәтләрен тәкъдирләп, Сафага бүләк бирделәр.* Безнең юл

**ТӘКЪДИРСЕЗ** *рәв.* Тәкъдир булмый торып, тәкъдир ителмәгән хәлдә. *Халкыбызның бөек улы булган Хәсәнгата Габәши мирасы бүгенге көнгә кадәр күтәрелмәгән чирәм хәлендә кала бирә, аның хезмәтләре тәкъдирсез калырга тиеш түгел.* Мирас

**ТӘКЪДИРЧЕ** *и. иск.* Язмышны алдан билгеләүче. *Ай-вай, Насретдин хан! Алла – тәкъдирче, бәндә – сәбәпче.* Н.Исәнбәт

**ТӘКЪЛИ́ДӘН** *рәв. гар. кит.* Кемгә дә булса ияреп, кемгәдер, нәрсәгәдер охшату юлы белән. *Искеләргә тәкълидән исмен «Китабеннас» куеп.* Ш.Бабич. *Бәетне һәркем үзе сөйгән көйгә җырлый. Алар күбрәк «Мөхәммәдия» көенә тәкълидән җырлана.* З.Акчурина

**ТӘКЪЛИДИ** *с. гар.* Ияреп ясалган, охшату юлы белән барлыкка килгән. *Аерым авазларның бер-берләрен алмаштыруы, бер-берсенә күчеше, озын сүзләрнең һаман кыскаруга омтылуы күп гасырлар, меңьеллыклар дәвам иткәнлектән, бик күп сүзләрнең тәкълиди чыгышы хәзер инде танылмый.* Р.Әхмәтьянов. *Бу тәкълиди кыйссаларның күбесе тәрҗемә ителергә дә тиеш түгел иде.* А.Тимергалин

**ТӘКЪЛИТ** *и. гар. кит.* Берәр эштә, кыланышта кемгәдер, нәрсәгәдер ияртү, охшарга тырышу күренеше. *Дөньяда һәр нәрсә тәкълиттән гыйбарәттер, дидем. Хәтта тәкълит без «габед»ләргә гыйбадәттер, дидем.* Ш.Бабич. *Мәрҗани билгеләвенчә, кешедә теге яки бу мәсьәләгә карата үз карашы һәрчак булмаска да мөмкин; әгәр бу шулай икән, ул әлеге очракта тәкълиткә мөрәҗәгать итәргә тиеш була.* А.Юзиев

2) *әд.* Башка берәүнең иҗат алымыннан файдалану, шуның стилен кабатлау. *Үзебезнең иске әдәбиятка һәм халык әдәбиятына тәкълит [Тукайның] аерым сөйгән бер нәрсәседер.* Җ.Вәлиди

**ТӘКЪЛИ́Т ИТҮ** *ф.* 1) Берәр эштә, кыланышта кемгә дә булса ияреп эшләү. *[Нәгыйм:] Безнең социалистларыбыз, гомумән алганда, русларга тәкълит итеп маташалар.* Ш.Камал

2) Төрле әдәби, фәнни, сәяси карашларга, ысулларга, теорияләргә сукырларча иярү

**ТӘКЪЛИ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **тәкълит итү**. *Кеше артыннан иярсәң дә, белеп тор: Шул вакытта иярүдән файда тияр; Белмәенчә тәкълит кылып юлга керсәң, Ахырында янган утка эчең көяр.* М.Гафури

**ТӘКЪЛИТЧЕ** *и. кит.* 1) Мөстәкыйль эш итәргә сәләте булмыйча, башкаларның эшен, кыланышын кабатлаучы

2) *әд.* Иҗат эшендә: берәр язучының, рәссамның стилен кабатлаучы, шулар үрнәгендә иҗат итүче. *Сүнчәләй, әлбәттә, гади эпигон-тәкълитче генә булмаган.* Р.Мостафин

**ТӘКЪЛИТЧЕЛЕК** *и. кит.* 1) Иярүчәнлек

2) *әд.* Тәкълиди әсәрләр язу белән мавыгу күрешене. *Вәлиди шагыйрьдәге сатираның көчен, үткенлеген, татар тормышындагы искелек, наданлыкны, торгынлыкны, тәкълитчелекне фаш итү сәләтен ассызыклый.* Т.Гыйлаҗев

**ТӘКЪРИЗ** *и. гар. иск.* Китапка яки язылган хезмәткә уңай рецензия, бәяләмә; *кирес.:* **тәнкыйть**. *Риза хәзрәтнең «Шура»дагы тәкъризенә канәгать кылмадым.* Х.Габәши. *Үз илемездә аз гына бер хөрлек булса, бу илле яшьлек Тукай хөрмәт ителер, бу хакта күп язулар, тәнкыйтьләр, тәкъризләр язылыр иде.* С.Чагатай

**ТӘКЪСИМ** *и. гар. иск.* Бүлү гамәле, кисәкләргә аеру эше

**ТӘКЪСИ́М ИТҮ** *ф. иск.* Өлешләргә бүлү, кисәкләргә аеру. *Янә икенче бабында: «Бер-бер адәм, ганә булып, хәсис булырса, --- бу адәмнең вафатыннан соңра, малы варисларына тәкъсим итеп бирелеп, хатыны нәфи ителер».* Ф.Халиди. *Бу егет әйтте: – Мин сезгә бүрек илә паласны тәкъсим итәем, – диде.* Мирас

**ТӘКЪСИР** *и. гар. иск.* Өлкәннәргә, руханиларга, дәрәҗәле затларга олылап эндәшү сүзе. *Тәкъсир ханым, сезләргә мин бер сүзем әйтәем…* Ә.Уразаев-Кормаши. *Әмир кумәччәнең караңгы*

*чыраен сизеп сорап куйган: – Я, – дигән, – кумәчең уңдымы? – Юк, тәкъсир, – дигән кумәчче, – миңа, әйбәт кумәч пешерү өчен, Сәмәрканд оны кирәк икән.* М.Мәһдиев

**ТӘКЫЙ** *рәв. иск.* Тагын, тагын да. *Гаеп тә, гаҗәп тә түгелдер, шәт, шушы яшькә җитеп, ни сәбәптән аерылышуларын беләсе килә. Ни дисәң дә, тәкый гаҗәп хәл булып тоелды ул миңа.* Ф.Баттал. *Җәбраил галәйһиссәлам назил булды, тәкый бу сүрәне пәйгамбәргә китерде.* М.Болгари

**ТӘЛӘЙ** *и. гар. диал. к.* **талигъ**. *Оланнарның тәләйләре булсын*

**ТӘЛӘЙЛЕ** *с. диал. к.* **талигълы**. *Тәләйле ана*

**ТӘЛӘКӘ** I *и.* 1) Бауларны борып кысу, тарттыру өчен кыска таяк, боргыч; *русчасы*: **закрутка, притужальник**. *Көлтәне тәләкә белән кысу*

2) Калкавыч, тәтәл. *Ю-юк, су дулкыны гына тәләкәне селкетә...* А.Гадел. *Көймә уртасындагы бердәнбер балыкчы үзенең нечкә саплы кармагын кул өстенә ыргыткан да, чын күңелдән ходайга гыйбадәт кылган кебек, тәләкәсенә карап оеган ---.* Казан утлары

3) Вәлүк, мичәү агачы. *Тәләкәне ныгыту. Тәләкәдән ычкындыру*

4) Суйган терлекнең тиресен тунау өчен, түшкәне асып куя торган ике башы киртләнгән таяк; тияк. *Сугым буласы көнне иртүк өйдә ыгы-зыгы куба. Кайнар су, зур-зур коштабаксавытлар, чормага ит асарга тәләкәләр әзерләнә.* М.Гали. *Икенчесе бүлтерекне тәләкәгә элеп, тиресен салдырды.* Казан утлары

5) Келә, капка биге. *Урамнан Аю Кәрименең капка тәләкәсе кадәрле генә сакау малае килеп керде дә бөтен ишегалдына ишетелерлек итеп сөрән салды.* Д.Салихов. *Жора, буе капка тәләкәсе кадәр генә булса да, үзе кыдрач, үзе бәйләнчек.* Ф.Абдуллин

6) Агач богау. *Хәзер генә тәләкәнең ни өчен куелуын аңлады Артык: чәркәгә туры китереп куелган тәләкә бөтенләй атларга бирми, аякларны шудырып кына барып була икән.* М.Хәбибуллин

7) Кыска агач таяк белән уйнала торган уен төре һәм шул таякчык үзе. *Аннан соң алар анда качышлы уйнадылар, тәләкә уйнадылар, йөгерештеләр.* Н.Фәттах

8) *күч. кимс.* Тәбәнәк буйлы, карсак кеше. *Кеше буйга үскән чакта, Кайда калдың, тәләкә?* Җыр. *Ул клубтагы тәләкә Шәмсиянең бер алдыңа, бер артыңа төшәргә торганын белмичә йөри бу димә.* Ф.Баттал

◊ **Тәләкә таягы** 1) Кемгә дә булса бер дә калмыйча ияреп йөрүче; 2) Кыска буйлы кеше турында. **Тәләкә кыздыру** Юк-барны сөйләп, бушка вакыт уздыру. *Капка төбендәге хатыннар янына туктап яки утырып тәләкә кыздырмый.* Г.Әпсәләмов

**ТӘЛӘКӘ** II *и. гар. диал.* Әләк. *Тәләкә кеше үтерер.* Мәкаль

**ТӘЛӘКӘЙ** *и. зоол.* Орчыксыман яки тамчысыман гәүдәле, су өстендә гадәттә көтүе белән хәрәкәт итүче су коңгызы; *русчасы*: **вертячка**

**ТӘЛӘФ** *и. гар. иск.* 1) Һәлак булу, бетү, юк булу

2) Әрәм булу, файдасызга туздырылу күренеше. *Саран малы – тәләфкә.* Мәкаль

**ТӘЛӘ́Ф БУЛУ** *ф.* Юкка чыгу, бетү, һәлак булу. *Әй кызым, бер өйдә ике җумарт булса, мал тәләф булыр.* К.Насыйри. *Бәлки, көпчәкне тәгәрәтергә безнең көчемез йитмәс, бәлки, без үземез тәгәрәткән көпчәкнең астында үземез калып тәләф булырмыз...* Г.Исхакый

**ТӘЛӘ́Ф ИТҮ** *ф.* 1) Юк итү, һәлак итү, үтерү. *Хабит итсәң, җанын тәләф итеп, хыянәт итмеш булырсың.* К.Насыйри

2) Әрәм-шәрәм итү, кирәксезгә сарыф итү, юкка чыгару. *Малыңны билкөлли тәләф итүдән саклан!* К.Насыйри. *Җитсен инде! Күп тәләф иттем сиңа елларны мин; Һай, тоталмам ахры, бик күп кудым җилләрне мин!* Г.Тукай

**ТӘЛӘ́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **тәләф итү**. *Аз заманда бар малын тәләф кылып бетерде.* К.Насыйри. *«Әгәр син Әстерханны олуг князь кулыннан алсаң, барыбер аны кулыңда тота алмассың, тагы олуг князь кире алыр. Бары тик кеше генә тәләф кылып калырсың», – дигән, имеш [солтанга Дәүләтгәрәй].* Г.Гобәйдуллин

**ТӘЛӘФФЫЗ** *и. гар. иск.* Авазларны чыгару, әйтү рәвеше, әйтелеш; сөйләмнең индивидуаль үзенчәлеге; акцент. *Әлеге мишәр таифәсе эченнән чыккан шагыйрь һәм язучыларны да, үз тәләффызларын ташлап, Казан шивәсендә язарга мәҗбүр итә торган иң көчле сәбәп шушы.* Г.Рәхим

**ТӘЛГӘШ** *и.* 1) Сирень, шомырт һ.б.ш.ларда гади чук чәчәк төркеме; *рус.:* **кисть**. *Халит карт кабере өстендә үскән сирень тәлгәшләре атынып алды.* Р.Батулла. *Шомырт тәлгәшләрен үбә-үбә, Тагын эңгер төшә, таң ата.* Г.Ибушев

2) Җиләк яки вак җимешләрнең бер сабакчыкта үскән чуклардан торган тупламы; *рус.:* **гроздь**. *Көзнең соңгы күрке булган миләш тәлгәшләре, шушы салкыннарда да ут кебек янып, тирә-якка ниндидер бер моңсулык сирпеп торалар.* М.Шабай. *Безнең авыл балаларының бик матур бер гадәте бар иде: савыт тулгач, өстенә, тәлгәше белән өзеп, сабаклы җиләк утырта идек.* М.Мәһдиев

3) Сабагы белән өзеп җыелган җиләк бәйләме. *Менә ылыс түшәк, кипкән яфраклар мендәре... Шунда ук кипкән җиләк-җимеш тәлгәшләре, чикләвек...* Г.Гыйльманов

4) Учма, бер тотам. *Йөзенә иннек сөртә, бит очына кара каләм белән миң төртә, маңгай чәчен кайчы белән кисеп, каш өстенә чәч тәлгәшләре төшерә.* Д.Каюмова. *Тагын бер тәлгәш чәч үремен бизәп балкыды.* Г.Әдһәм

5) *күч.* Нәрсәләрнең дә булса җыелмасы, бер урындагы тупланмасы. *Аңа булган Халык Мәхәббәте сыярмыни шигъри тәлгәшкә?* Р.Әхмәтҗан. *Үзенчәлекле шигъри бәйрәмнән һәркем үзенең күңеленә яткан илһам, моң, хис тәлгәшләре алып китте.* Якты юл

**ТӘЛГӘШЛӘНҮ** *ф.* Тәлгәш рәвешенә килү, тәлгәш булып оешу; тәлгәшләр хасил булу. *Кызым канлы башын күтәргән! Күзләрендә кайнар яшьләре; Тәлгәшләнеп төшкән чәчләре Манчып алган кебек – кан гына...* Ф.Кәрим. *Ә багларда йөземнәр тәлгәшләнгән. Тиздән гаҗәеп җимешләр өлгерер!* Р.Гаташ

**Тәлгәшләнә башлау** Тәлгәшләнергә тотыну

**Тәлгәшләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча тәлгәшләнү. *Әле яшь кенә булуына карамастан, юылмаган, тәлгәшләнеп беткән чәчләр, пычрак киемнәр, бөкшәйгән кыяфәт аны хәлсез карчыкка әйләндергән.* Шәһри Казан

**Тәлгәшләнеп килү** Акрынлап тәлгәшләр хасил булу. *Сабан культуралары 2–3 яфраклы булып тәлгәшләнеп килә.* Бөгелмә авазы

**ТӘЛГӘШЛӘП** *рәв.* Аерым тәлгәшләр рәвешендә; тәлгәш-тәлгәш итеп; тәлгәшеннән аермыйча, өзмичә; тәлгәше белән. *Чиләк өстенә тәлгәшләп җыйган иң матур җиләкләрне салды.* З.Кадыйрова. *Җиләкне чиләккә түгел, тәлгәшләп кенә җыя алдылар.* Казан утлары

**ТӘЛГӘШЛЕ** *с.* Тәлгәш рәвешендәге; тәлгәшләре булган. *Стенага тәлгәшле җиләкләр, баланнар, миләшләр эленгән.* Ф.Яруллин. *Ак тәлгәшле сирень алыргамы әллә?* М.Маликова

**ТӘЛГӘ́Ш-ТӘЛГӘШ** *с.* **1.** Аерым тәлгәшләр булып укмашкан, күп тәлгәшләр рәвешендәге. *Ишегалларында розалар чәчәк атып утыра, бакчаларында тәлгәш-тәлгәш йөзем җимешләре асылынып тора.* Ф.Яруллин. *Авылда көз. Урам бакчаларда Тәлгәш-тәлгәш балан.* Ф.Гыйләҗев

**2**. *рәв. мәгъ.* Тәлгәшләп, тәлгәше белән; тәлгәшләр рәвешендә. *Ботак очларында тәлгәш-тәлгәш булып тезелешкән баланнарга ут кабынганмыни!* В.Имамов. *Башакларда инде серкәләр тәлгәш-тәлгәш асылынып торалар.* Казан утлары

**ТӘЛИНКӘ** *и. нем.* 1) Бераз күтәрелеп торган кырыйлы, киң, яссы төпле сай савыт. *Апа, бер кулына ак шадра тастымал алып, чәй тәлинкәләрен сөртергә кереште.* Р.Мөхәммәдиев

2) Шул савытка сыешлы әйбернең чама, үлчәм күләме. *Эш беткәч, ашсуга чакырып, бер-ике тәлинкә майлы коймак, яшел суган турап, коштабак түбәләмә әзерләнгән бәрәңге боламыгын ә дигәнче җимереп бирә*... М.Мәһдиев. *Төшлектә бер тәлинкә сөтле аш, катык-фәлән, чәй белән тәгамләнерсең.* Г.Мөхәмметшин

3) Үлчәүнең берсенә гер, икенчесенә үлчәнәсе әйбер салына торган савытларның һәрберсе. – *Тукта әле, Бибисара апа, – диде Сәхипҗамал җиңги. – Үлчәү тәлинкәләре дә, тигез итеп салмасаң, берсе өскә күтәрелә, икенчесе аска төшә.* Г.Әпсәләмов. *Дөнья бер мәлгә тигезләнеп калган үлчәү тәлинкәләре хәлендә килә.* Ф.Яхин

4) *радио* Репродукторга килгән кечкенә амплитудалы тирбәнешләрне зурайтыр өчен куела торган түгәрәк тавыш көчәйткеч; диффузор

5) Патефон, граммофон һ.б.ш.ларның тавыш язылган пластинкасы; диск. *Күпме патефон тәлинкәсе, аудиокассета, компакт-дисклар ярылып, сытелеп, кырылып, өелеп ята, чүплеккә чыга.* К.Кәримов. *1988 елда композитор Рәшит Кәлимуллин әсәрләреннән торган музыкаль тәлинкә дөнья күрде.* Г.Шәйхи

6) *тех.* Авыл хуҗалыгы машиналарында җирне кисеп бара торган яссы металл диск. *Иярткүче һәм ияргүче тәлинкәләр аралаш җыелган, тәлинкәгә барабан ишекләре аша чыккан шпилькалар борылган.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Күмдерү тәлинкәсе. Чәчкеч тәлинкәсе. Тормоз тәлинкәсе*

7) Фермаларда терлек-туарны, кошкортны автоматик рәвештә эчертү өчен кулланыла торган савыт. *[Көтүчеләрнең берсе:] Безнең фермага автоматик эчертү кертелә бит. Сыер борынын китереп төртү белән су чыгара торган теге тәлинкәне беләсеңдер инде. Шул инде, әнә шул, улак төбенә беркетеп куялар бугай аны.* Г.Галиев

8) Сепарат барабаны эчендәге катлыкатлы бүрәнкәсыман детальләрнең һәрберсе. *Сабира, сепарат тәлинкәләрен юган җиреннән бүленеп, верандага ашыкты.* Н.Харисова

9) *күпл.* **тәлинкәләр**. Ике түгәрәк калайдан гыйбарәт бәрмә уен коралы. *Ул Казан танк училищесындагы оркестрда барабаннарда һәм тәлинкәләрдә уйный.* Безнең гәҗит

10) *тех.* Вагоннар бер-берсенә каты бәрелмәсен өчен, алар арасындагы тормоз җайланмасының ике яссы түгәрәк тимердән гыйбарәт өлеше. *Поезд туктады, вагон тәлинкәләре берберләренә бәрелеп алдылар.* Безнең юл

11) Батынкы түгәрәк формасындагы телевизион антенна. *Энгель агай салам түбәсе бер якка авышкан абзар кыегына космос аша телевизор карый торган тәлинкә кагып маташа иде.* К.Кәримов. *Спутник тәлинкәләре хәзер шәһәр халкында гына түгел, авыл җирендә дә мулдан.* Шәһри Казан

12) *сир.* Көнбагыш, ромашка, кашкарый һ.б.ш. үсемлекләрнең орлык үсә торган түгәрәк өлеше. *Җәй, урак өсте. Бакчаларда, сары тәлинкә булып, көнбагыш көлэчләнеп утырган вакыт.* М.Мәһдиев

◊ **Тәлинкә яздыру** *этн.* Элек эче авырткан кешеләргә тәлинкәгә зәгъфран кара белән язылган доганы чайкап эчерүдән гыйбарәт дәвалау ысулы. *Бу бай гына бер тол хатын булып, Разия исемле бердәнбер кызы бик күптәннән бирле урын өстендә иде. Кызына чайкап эчерү өчен тәлинкә яздырырга килгәндер әле, яки бөти-мазар.* Г.Гобәй. *Яшь хатынның тәлинкә яздырып эчертүе, өшкертү-төкертүләре генә, әлбәттә, бер файда да бирмәгән иде.* Ф.Хөсни. **Тәлинкә тоту** Гадәттә үзеннән өстен кешеләргә яхшатланып ярарга тырышу, ялагайлану. *Мәҗлесләргә хәзер туганнарны чакырмыйлар, күбрәк башлыкларга, төшемле урындагы кешеләргә тәлинкә тоталар.* А.Гыйләҗев. *[Нәҗип:] Ярар, персидәтелгә булсын да ди, ул хуҗа кеше... Хуҗа кеше алдында тәлинкә тоткан бер син генә түгел.* Р.Мөхәммәдиев. **Тәлинкә ялау** *к.* **тәлинкә тоту**. *Тик аларның максаты Түрәгә ярау икән, Эшче фәкыйрь канын эчеп, Тәлинкә ялау икән.* Г.Камал. *Нәҗип Камалны телгә алдылар – аны идарә яклы дип, байлар, хәзрәт-хәлфәләр тәлинкәсен ялый дип, кире суктылар.* Г.Ибраһимов. **Тәлинкәсен башына каплаган** Оятсыз, әрсез; куштан, ялагай

**ТӘЛИНКӘ-КАШЫК** *җый. и.* Табында, ашаган-эчкәндә кирәк булган вак савыт-саба һәм кашык, чәнечке кебек төрле кирәк-ярак; аш приборлары. *Моннан ары бу хәзрәткә аш бүлмә, алдына тәлинкә-кашык куйма!* М.Галәү. *Шундук хезмәтче кереп, өстәмә тәлинкә-кашык куйды.* Ф.Тарханова

**ТӘЛИНКӘЛЕ** *с.* 1) Нинди дә булса тәлинкәсе булган. *Күрше буп-буш лавкага тәлинкәле үлчәү китереп куйдылар.* Т.Нурмөхәммәтов

2) Тәлинкә формасындагы. *Алай-болай көчле җил чыгып очырмасын өчен, тәлинкәле антеннаны дилбегә кисәге белән кайчылыкка да тартты-рып куйды.* К.Кәримов. *Шуннан бирле сугыш минем күз алдыма шул тәлинкәле кара репродуктор булып килеп баса.* Казан утлары

3) *тех.* Эш башкару детальләре тәлинкәләрдән (*6 мәгъ.*) торган. *Без килгән көнне егет көзге игеннәрне чәчүгә җир әзерләү (тәлинкәле тырма белән эшкәртү) белән шөгыльләнә иде.* Тәтеш таңнары. *Тәлинкәле чәчү машинасы. Тәлинкәле культиватор*

**ТӘЛИНКӘ́-ТӘЛИНКӘ** *рәв.* Тәлинкәләре белән, тәлинкәләргә салып. *Фәйзулла мәзин белән Хаҗиморат хәзер генә табадан төшкән коймакларны, ләвәшләрне, бавырсакларны тәлинкә-тәлинкә кунаклар алдына таратып, чәй ясый башладылар.* Г.Ибраһимов. *Хатыннар коймак пешерә, хуҗаның малайлары, тәлинкә-тәлинкә өеп, кунакларга коймак ташый, чәй ясыйлар, китүчеләрне озатып калалар, килүчеләрне каршы алалар.* М.Галәү

**ТӘЛИНКӘЧЕ** *и.* 1) Очып йөри торган билгесез объектта килгән чит планета вәкиле. *Янә тәлинкәчеләр төшкән, һәм кайсы җан иясенә акыл орлыгы салып калдыру хакында бәхәс куптан.* Р.Зарипов

2) Ялагай, юмакай кеше. *Байның якыннарымы, тәлинкәчеләреннәнме, --- минем сүземне зурайтып, байга ирештергәннәр.* Г.Ибраһимов

**ТӘЛКЫЙНЬ** *и. гар. иск.* 1) Берәр фикерне, сүзне кемгә дә булса әйтеп тору, төшендереп күңеленә салу. *Ләкин ул, минем тәлкыйнемә бер дә илтифат итмичә, һаман да «я» һәм «шин» хәрефләрен тәкрар итә иде.* Г.Тукай

2) *дини* Мәетне күмеп, озатучылар киткәч, гадәттә мулланың, кабер янында калып, мәрхүмне исенә төшереп шәһадәт сүзләрен уку гамәле

**ТӘЛКЫЙНЬ ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса күңелгә салу, әйтеп тору, өйрәтү; төшендерү. *Шулай да әчке бер сизенү аңа бу музыканың да мәктәптә булган башка тилерүләр, әдәпсез уеннар --- кебек, хәзрәт булмаганда гына, бөтен дөньядан яшереп кенә эшләргә ярый торган бер нәрсә икәнен тәлкыйнь итә.* Г.Ибраһимов

2) Тәлкыйнь (*2 мәгъ.*) йоласын үтәү

**ТӘЛКЫ́ЙНЬ КЫЛУ** *ф. к.* **тәлкыйнь итү**. *[Сәгыйть хәзрәт:] Без иман тәлкыйнь кылырмыз, сез шуны шуларга аңлатырсыз.* Г.Исхакый

**ТӘЛЛӘТӘВЕЧ** *и. зоол.* Шөлди кошлар семьялыгыннан Евразиянең урман зонасында яши торган озын томшыклы, кара түшле, кызгылт көрән каурыйлы кош; урман шөлдие, вальдшнеп. *Татарстанда урман шөлдие – тәлләтәвеч һәм яр шөлдие – корыхтан очрый.* Табигать хәзинәсеннән ашлар. *Тәлләтәвеч җылы яклардан апрель урталарында килә.* Зоология

**ТӘЛПӘК** I *и. диал.* 1) Колакчынсыз баш киеме; кәләпүш. *Чиллэдә дә сырган чалбарын, кара тәлпәген киеп, көннең көнендә авыл читендә, инеш буенда урнашкан алачыгына төшәр Ярулла бабай.* Т.Галиуллин. *Чикәләреннән үк башланган сакалы йөзен япкан, кәгазьдәй ак чәчләре тәлпәге астыннан маңгаена төшкән.* Л.-Х.Таналин

2) Самавыр калпагы

**ТӘЛПӘК** II *с. диал.* Киң, җәенке һәм тәбәнәк. *Ташлы тәлпәк тау төбеннән агып чыккан чишмә әллә ни зур түгел.* С.Лашманчы

**ТӘЛПӘЮ** *ф. диал.* Җәелү һәм юкару. *Бәләкәй генә иске түбәтәй --- хуҗасының баш очына менеп, тәлпәеп кенә утырган.* Ш.Маннур

**ТӘЛПИ** *и. диал.* Күп сөйләшә торган, сөйләмчәк кеше, такылдык. *– Кайсы Әхмәтҗанны? – диде минем соравыма каршы хатыннарның кечерәк буйлысы. – Тәлпи Әхмәтҗанны!* Ә.Еники

**ТӘЛПИЯК** *и. зоол.* Карп балыклар семьялыгыннан Европа сулыкларында киң таралган ачык көмешсу төстәге балык; *русчасы*: **густера**. *Тәлпияк судагы төрле организмнар белән туклана, уылдыгын үсемлекләр өстенә чәчә.* Зоология

**ТӘЛТӘВЕЧ** *и.* 1) **калкавыч**. *Кармакның тәлтәвеченә кызыгып теңкәмә тиделәр.* Н.Әхмәдиев. *Аязның бер тәлтәвече көймәне селкетерлек итеп дырылдарга керешә.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **тәлләтәвеч**. *Аларга хәзер киек казлар, көтү-көтү кыр үрдәкләре, тәлтәвечләр ял итәргә төшәләр.* М.Хәсәнов

**ТӘМ** *и.* 1) Авыз куышлыгының һәм телнең лайлалы тышчасы ризык, эчемлек һ.б.ш. белән ярсытылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән биш тышкы тойгының берсе; шул рәвешле тою сәләте; тат. *Гөлбану үлмәде, ләкин авызында тәм бетте, тормышыннан ямь тапмас булып калды.* Г.Ибраһимов

2) Телдә, авызда билгеле сыйфатлы ризыкка, эчемлеккә карата барлыкка килгән тойгы һәм шуларның теге яки бу тойгы тудыра торган үзенчәлекле сыйфаты. *Әремнең тәме бик ачы, хәтта әрем ашаган хайванның сөтенә һәм итенә әрем тәме чыга.* К.Насыйри. *[Насибулла абзый:] Ну инде Черемховога барып җитсәң... Анда су бөтенләй икенче. Үзе кызгылт сыман, үзеннән тимер, бакыр тәме килә.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Берәр тойгы кичерүдән туган рәхәтлек хисе; ләззәт. *Гариф абый очрашкан саен шул вакыйганы искә алып, --- тулыландыра барудан тәм, эчке ләззәт табып сөйләвен белде.* Т.Галиуллин. *[Кәримә:] Телне яратырга өйрәтәм. Туган телнең ләззәтен, тәмен тоярга!* Р.Мулланурова

◊ **Тәм алу** Күңелгә ятышлы нәрсәдән ләззәт тою, ләззәтләнү. *Шагыйрь дә шулай тормыштан тәм ала.* Ш.Галиев. **Тәме йөгерү** Берәр нәрсәнең рәхәтен, ләззәтен тоеп алу; михнәтен, авырлыгын аңлый башлау. *Ашыкма. Исәпләсеннәр, сынасыннар. Табышның тәме йөгерсен! Аннары үзеңне уч төбенә генә утыртып, кадерләп йөртерләр.* К.Тимбикова. **Тәме китү** 1) Берәр нәрсәнең ләззәте, рәхәте юкка чыгу, кызыгы калмау. *Көчләп күрсәтелсә, шәфкатьнең дә тәме китәдер, андый миһербанлылыкны җирле халык ишетергә дә теләмидер.* Т.Әйди. *Кызының каенанасына начарлыгы өчен авыл халкы кырын күз белән карый күк төсле тоелганга, яшәвенең тәме кит-

*те ---*. Р.Рахман; 2) *к.* **тәме йөгерү**. **Тәм керү** 1) Үзенә хас тәм алу. *Шомыртка чыпчык кунган, тәм кергән микәнни?* Ф.Яхин; 2) Тәмсезләнү, исләнү; сасый, сөрси башлау. *Чери башлаган алмалар, тәм кергән эремчек-каймаклар бәлешләргә кереп китә.* Шәһри Казан. **Тәмен белеп** Ләззәт табып, рәхәтләнеп, иркенләп (яшәү, ашау-эчү, сөйләү, эшләү һ.б. турында). *Гатият абзый сүзнең тәмен белеп, сюжет корып сөйли иде.* М.Мәһдиев. *Тормышның кадерен, тәмен белеп яшәгән кеше икәнлеге күренеп-сизелеп тора.* Т.Галиуллин. **Тәмен белү** Берәр нәрсәнең яки эшнең рәхәтен яисә михнәтен аңлау, сизү, тату. *Ирләр андый сөйләшүнең тәмен беләмени: Әбүзәр абзый, коридорга чыгып, үзе кебек китап сөюче бер танышына шалтыратты.* Г.Әпсәләмов. *Ә «Казан утлары»ннан башка әдәбият дәресләре кызыклы үтә алмый, укучыларны бүгеннән үк журналны укырга күнектерергә, тәмен белергә өйрәтергә кирәк.* Р.Фәйзуллин. **Тәмен җибәрү** Берәр нәрсәнең матурлыгын, җаен, рәтен бозу, ләззәтен, кызыгын юкка чыгару. *Юк, сүзнең тәмен җибәрәсем килмәде.* Г.Тарханова. **Тәмен китәрү** *к.* **тәмен җибәрү**. **Тәмен сизү** *к.* **тәмен белү**. **Тәмен тату** *к.* **тәмен белү**. *Казан тәхете – Мәскәү тәхетенә тиң тәхет. Тәмен татып карады инде, белә.* М.Әмирханов. **Тәм табу** *к.* **тәм алу**. *– Шулай да, – диде, – монда кайтыр идек. Караюрганы бик сагынабыз, җирнең ямен тапмыйбыз, суының тәмен тапмыйбыз, – диде [Мәрхәбә].* Г.Ибраһимов. *[Приказчиклар] Тәмен табып, ниндидер бер ләззәт белән бөтен шәһәрнең гайбәтен сатарга керешәләр.* М.Шабай. **Тәм тату** Нәрсәнең нәрсә икәнлеген аңлап, ярата, ошата башлау, рәхәтен күрү. *Укуның тәмен татыдым, парень!* Г.Кутуй. *Безгә дә ванналы, газлы тормышның тәмен татып калырга чират җиткән, диләр.* Г.Әпсәләмов

**ТӘМАМ** *хәб. сүз* **1.** Берәр эшнең азагына җитүе, төгәлләнүе турында. *Конфетны әллә суырып бетерде, әллә йотып җибәрде ул бераздан, тамаша тәмам дигәнне аңлатып, җитдиләнеп калды маймылыбыз.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бөтенләй, бөтенләе белән, тулысынча. *Тешең төшеп, тәмам картайгансың, тәмам эштән чыгып беткәнсең!* М.Гафури. *Исламның машинасы капка төбенә бүген дә тәмам караңгы төшкәч кенә килеп туктады.* С.Шәмси

2) Нәкъ, төп-төгәл, тач, там, тулысынча. *«Чабаталы түрәләр»дән берсе тагы тәмам начальникларга охшаш бер тавыш белән: – Әй, никрутлар! Тизрәк җыелыгыз, каралырга кертәбез! – дип кычкырды.* Г.Ибраһимов

**3.** *с. мәгъ. иск.* Мөмкин булган барлык, тулы. *Һәм үз сүзен итте: үзенең зур чанасына пар атын кыңгыраулар тагып җиктерде дә, кучер утыртып, тәмам тантана белән озатты.* Г.Ибраһимов. *Эшчеләр --- тәмам иркенлек булсын өчен көрәшәләр.* Урал

**4.** *и. мәгъ.* Ахыр, азак, соң. *Омтыламын үзем офыкларга, Юлларымның юктай тәмамы.* И.Киньябулатов

◊ **Тәмам тәмамына** *иск.* Бөтенләй, тулысы белән, ахыргача. *Болар – тәмам тәмамына бер сыйныф халыкка хезмәт итүчеләр.* Г.Камал. **Тәмамы белән** Ахырына кадәр, тулысынча. *А.Гыйләҗев алдан ук укучысын юлның тәмамы белән таныштыра.* Г.Гайнуллина

**ТӘМА́МӘН** *рәв. гар.* Бөтенләй, тулысынча. *Ләим [саран] кешенең хаҗәтен тәмамән әда кыйлсаң да, сиңа явызлыгын тидерер.* К.Насыйри. *Цензор дигән нәрсә матбугат өчен тәмамән бетерелде.* Г.Исхакый

**ТӘМА́М БУЛУ** *ф.* Төгәлләнү, бетү, башкарылып чыгу, тәмамлану. *Быел игеннәр бик уңган булса да, көннәр коры булу сәбәпле, ялан эше үз вакытында тәмам булды.* Г.Ибраһимов. *Хәзрәт белән хәлфә абыйның сүзләре нәрсә белән тәмам булгандыр, белмим.* Г.Гобәй

**ТӘМА́М ИТҮ** *ф. к.* **тәмамлау**. *Ястүдән соң, бер парә Коръәнен тәмам итеп, Фатыйма бикә дә рәхәт йокыга бирелә.* Г.Ибраһимов. *Атай кылычны төргән бигаять озын киндерне чишәчишә тәмам итеп, кылычны кынысыннан чыгарып, бик гайрәт белән чаж итеп селкеп җибәрде.* Г.Газиз

**ТӘМА́М КЫЛУ** *ф. к.* **тәмам итү**. *Ураза тотарга теләгән кешеләр таң беленгәнче сәхәрләрен тәмам кылырга тиеш булалар.* Авыл офыклары

**ТӘМАМЛАНУ** *ф.* 1) Берәр эш ахырына кадәр башкарылып чыгу, төгәлләнү. *Быел имтиханнар июль башында тәмамланырга тиеш.* Ф.Яруллин. *Мәҗлеснең беренче өлеше компот, кесәл эчкәннән, карбыз яки җиләк-җимеш (кем нәрсә тели) ашаганнан соң тәмамлана.* Татар халык ашлары

2) Чикләнү, бетү. *Бу дөнья бит минем өчен бик кечкенә булган әле ул чакларда, туган авылымнан башланып туган авыл белән тәмамланадыр кебек тоелган.* Р.Мөхәммәдиев

**Тәмамлана башлау** Тәмамлануга якынлашу. *Ә ай тәмамлана башлагач, ничектер кисәк үзгәреп, үзенә урын таба алмый башлый: борчыла, бәргәләнә.* Саба таңнары

**Тәмамлана төшү** Беразы тәмамлану. *Өй арасындагы эшләр тәмамлана төшкәч, Наилә тирәсендә ике-өч тапкыр сәер генә уралып-чуралып йөргән карчык, авызын учы белән каплап, аңа дәште.* А.Гыйләҗев

**Тәмамлана язу** Чак тәмамланмый калу. *Казанда «Авиатөзелеш районы» идарәче компаниясе эшчеләренең йортның авыш түбәсен чистартулары һәлакәт белән тәмамлана язды.* Шәһри Казан

**Тәмамланып бару** Акрынлап тәмамлануга якынлашу. *Башлангыч мәктәптә укуларыбыз тәмамланып бара, контроль эшләр бер-бер артлы килә, бик тиз арыйбыз.* Ф.Яхин

**Тәмамланып килү** Тәмамлануга табан бару. *Шундый газаплар һәм өметләр белән хезмәте тәмамланып килгәндә, Казаннан бандероль килеп төште.* С.Шәмси

**Тәмамланып кую** Кинәт тәмамлану. *Аның уены илнең иң тәҗрибәле тренерлары өчен дә еш кына һич көтелмәгәнчә башлана, уйламаган нәтиҗәләр белән тәмамланып куя.* К.Тимбикова

**Тәмамланып тору** Хәзерге моментта тәмамлану. *Кыңгырау чыңлавы тавышы эзеннән Карга авылы мәктәбенә барып керсәк, укытучыларның ярышконкурсы тәмамланып тора, язучылар*

*белән очрашу икесе бергә ялганып китте.* Б.Рәхимова

**ТӘМАМЛАНЫШ** *и. сәнг.* Музыка, сәхнә яки әдәби әсәрнең ахыргы өлеше, соңы; финал. *Сабирның явыз көчләр тылсымыннан котылып, --- балачак уенарына кире әйләнеп кайтуы татар әкиятләренең оптимистик тәмамланышы белән туры килә.* И.Фазлетдинов. *Тәүге интонацияне көчәйтеп, башланыш һәм тәмамланышта бербөтенлеккә ирешеп, гармония хасил итә ул.* Х.Назар

**ТӘМАМЛА́У** *ф.* 1) Берәр эшне ахырга кадәр башкарып чыгу, бетерү, төгәлләү. *Остазбикә --- тиз-тиз генә эшләрен тәмамлады да өмет вә шөбһә эчендә ире янына чыкты.* Г.Ибраһимов. *Син һәр язучының иҗат гомерендә була торган иң олы эшеңне тәмамлап нокта куйдың бит инде.* М.Галиев

2) Берәр эш яки сүзнең азагын нәрсә белән дә булса төгәлләү, бетереп кую. *Әти-әниләр, соңыннан ясалма каршылык тудырып, хатларын ультиматум белән тәмамлый.* Безнең гәҗит

3) Билгеле уку йортында укып чыгу. *Профессор Әбүзәр Таһиров – татарлардан беренче врачларның берсе, әле мең тугыз йөз унберенче елда ук Казан университетының медицина факультетын тәмамлаган.* Г.Әпсәләмов. *Элегрәк Латвиягә килгән татарларның күбесе үз вакытында татар мәктәпләрен тәмамлаган.* Мәдәни җомга

**Тәмамлап йөрү** Әле, хәзерге вакытта тәмамлау. *Айрат Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап йөри икән.* Г.Шәйхи

**Тәмамлап килү** Акрынлап тәмамлауга таба якынлашу. *Көз үз эшен тәмамлап килә икән инде: агачлар нинди генә төсләргә буялмаган!* М.Яһудин

**Тәмамлап кую** Тәмамланган хәлгә китерү. *Мәкаль кайвакыт әкиятнең эчтәлегенә йомгак рәвешендә азакта килеп, аны тәмамлап куя.* Л.Җамалетдинов

**Тәмамлап чыгу** Тулысынча тәмамлау. *Әмма егерме дүрттә ул санитарий врачы дипломы алып институтны тәмамлап чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Бишалты ай эчендә шуларны (романнарны) тәмамлап чыксам, начар булмас.* Г.Бәширов

**Тәмамлый башлау** Тәмамлау гадәте алу. *Игътибар итәсездер, Мәскәү телеканаллары соңгы вакытта күпчелек тапшыруларына анонсларын «Смотри, Россия» дип тәмамлый башлады.* Ватаным Татарстан

**ТӘМАМЛЫК** *и. лингв.* Җөмләнең кыек килештәге исем белән белдерелә торган иярчен кисәге. *Тәмамлык – җөмләнең процесс белдерүче сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә иярә ала.* Татар синтаксисы

**ТӘМАМЛЫ́К ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Баш җөмләнең тәмамлыгы булып килә торган иярчен җөмлә

**ТӘ́МАМ-ТӘМАМ** *рәв.* 1) Тулысынча, бөтенләй. *Менә шунда сабыр савытларым тәмам-тәмам тулып ашты минем.* Р.Төхфәтуллин

2) Төп-төгәл, нәкъ, тач. *Канатлары да, койрыгы да, башы да бар – тәмам-тәмам тилгәнгә охшаган, дип күңеленә беркетеп куйды.* Г.Кадыйров

**ТӘМАМЫ́НЧА** *рәв. иск.* Ахырына, азагына җиткереп; тулысынча. *Өченче ел бәрәңге казып бетергән көнне кичен Габдияр картның сул күз бәбәге тәмамынча томаланды.* М.Хуҗин

**ТӘМА́МЫСЫ** *рәв. сөйл.* Бөтенләй, тәмам, нык. *Бүреләр тәмамысы азынды!* А.Гыйләҗев

**ТӘМӘЙТҮ** *ф. диал.* 1) Тәмле тәм кертү, тәмле итү

2) Билгеле тәм төсмере бирү, берәр тәм кертү. *Алма янында яткан бәрәңге алма тәмәйткән, бәрәңге янында яткан алма бәрәңге тәмәйткән.* Мәкаль

3) Татып карау, тәмен белергә тырышу. *Гүя ул «таныш фамилияне» телендә тәмәйтеп карый иде.* А.Хәлим

**Тәмәйтеп тору** Берникадәр вакыт тәмәйтү. *--- ап-ак сыеклыкны чынлап та «әҗәл даруы» микъдарында гына кечкенә зәңгәрсу савытка сала һәм, савытны авызына каплаганнан соң, телләре белән аңкавын бераз тәмәйтеп тора ---.* А.Хәлим

**ТӘМӘКЕ** *и. фар.* 1) *бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан никотинлы культура буларак игелә торган, озын сабаклы, бер яки күпьеллык үлән үсемлек. *Тәмәкенең күп төрләрендә (башлыча яфракларында) агулы никотин алкалоиды бар.* Биология. *Электә Кырым татарлары да бик яхшы тәмәке сортлары үстерә белгәннәр.* А.Тимергалин

2) Шул үсемлекнең ваклап туралган, төелгән коры яфракларыннан гыйбарәт тарту, иснәү, чәйнәү өчен әзерләнгән масса. *Бабай икенче тапкыр челеменә яфрак тәмәке тутырды, чакма таш сугып яндырды, куе төтен таратып, тартырга тотынды.* Г.Ибраһимов. *Тәмәкене телгә алганда, бу кеше автомат рәвештә кесәсенә кулын тыга, кайвакытта янчыгын да сөйрәп чыгара.* М.Мәһдиев

3) Әлеге массаны тутырып тарту өчен ясалган папирос, сигарет һ.б.ш. нәрсәләрнең гомуми атамасы. *Биш-алты ир-атның ярышкандай өзлексез тартуыннан, тәмәке төтене дә балта асарлык булып куерган иде.* М.Хәсәнов. *Эх, бер тәмәке тартасы иде.* Х.Камалов

**ТӘМӘКЕ́ГӨЛ** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан яфраклары тәмәкенеке шикелле, чәчәкләре төрле төстә булган хуш исле декоратив үсемлек; *русчасы:* **табак душистый**

**ТӘМӘКЕЛЕ** *с.* Тәмәке (*1 мәгъ.*) үскән яки тәмәке (*2 мәгъ.*) тутырылган. *Ул, вакытым юк, дигәч, Ярулла тәмәкеле капчыгын күрсәтте.* Г.Гыйззәт

**ТӘМӘКЕЛЕК** *с.* 1) Тәмәке өчен җитәрлек. *Менә минем бит тәмәкелек тә акчам калмады.* Н.Акмал

2) Тәмәке өчен махсус кулланыла торган. *Булатов өстәл өстендә яткан бер газета почмагыннан тәмәкелек кәгазь ертып маташа иде.* Н.Фәттах

**ТӘМӘКЕЧЕ** *и.* 1) Тәмәке тартучы, тәмәке тартырга яратучы. *Арада Әхәттән бүтән тәмәкече юк иде.* Г.Бәширов. *Араларында теге ике тәмәкече дә кереп, Хәлим яныннан затсыз ис калдырып узып киттеләр, түргәрәк атладылар.* Ф.Яхин

2) Тәмәкечелек хезмәткәре, тәмәке эшкәртү белгече

3) Тәмәке сатучы. *Бүлмәне кояш нуры төсле яктыртып, ишектә тәмәкече кыз күренде.* К.Тинчурин

**ТӘМӘКЕЧЕЛЕК** *и.* 1) Азык-төлек сәнәгатенең тәмәке игү, эшкәртү һәм сату белән шөгыльләнә торган тармагы. *Тәмәкечелек – яхшы табыш китерә*

*торган тармак. Бик күп хезмәт һәм, нигездә, кул хезмәте таләп итә иде.* М.Гыймадиев

2) *сөйл.* Тәмәке тартуга әвәслек, тәмәке тарту гадәте. *Бүгенге көндә тәмәкечелек белән көрәшү өчен күп кенә программалар бар.* Г.Хәбибуллин. *Тәмәкечелек тарихы әллә кайларга барып тоташа. Колумб Американы ачканнан соң, ул бик тиз Җир шарын камап алган.* Р.Кәрәмуллин

**ТӘМӘЛ** *и. гар. иск.* 1) Нигез, фундамент. --- *чит илдә --- әдәбиятымыз берлә таныштырганда, сезнең әдәби әсәрләрегез тәмәл ташы урынын тотадыр.* Х.Миңнегулов

2) Килеп чыгыш

3) Даими яшәү урыны; чыгыш, ата-анасының хезмәтен белдергән мәгълүмат. *Аның социаль тәмәле*

**ТӘМГЫ** *и. иск. к.* **тамгы**. *Азгынның тәмгысы тәртә буе.* Мәкаль

**ТӘМЕК** *и. бор.* Мишень, һәдәф, мәрәй. *Туры ук тәмеккә тияр, кәкре җәя – кулда калыр.* Мәкаль

**ТӘМИ** *и диал.* Тәм белүче, ашамлыкның тәмен билгеләүдә маһир кеше; дегустатор

**ТӘМИЗ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Чиста, ару. *Хастаханә бик тәмиз, хасталарның һәм ята торган урыннары да пакь һәм ак.* Г.Камал. *Мөселман мәктәбе үзенең гүзәл вә тәмиз форма кигән сөйкемле шәкертләре аша бөтен Токиога мәгълүм булганга, аларны юлда күргәннәр туктатып: «Син мөселманмы?» – дип сөеп китәләр.* Гасырлар авазы

2) Саф, пакь, эчкерсез. *Тәмиз күңелле кеше*

**2.** *рәв. мәгъ.* Чиста хәлдә, ару килеш; чиста итеп. *Һәркаюсы яхшы, тәмиз киенгәннәр. Гүяки бәйрәм итәләр.* Г.Камал

**ТӘМИЗЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тәмизләү**. *Һәйбәтләп тәмизләнгән мунчага һушыңны алырлык тәмле исләр таралды.* Сөембикә

2) *кайт. юн. к.* **тәмизләү**

**ТӘМИЗЛӘ́Ү** *ф. кит.* Чистарту, тазарту, пакьләү, арулау. *Ул [су] да ярамаса, елганың чыга торган җирен суны боза торган нәрсәләрдән тәмизләмәк, пакьләмәк тиеш буладыр.* З.Һади. --- *алганнан соң ул алтыннарны тәмизләп, сатып бетерергә кирәк булачак, сәүдәгәр булмаган кешегә бу да – бер читен эш.* Г.Камал

**ТӘМИЗЛЕК** *и. кит.* Тәмиз булу, чисталык, пакьлек. *Лондонда Париждагы кеби мәһабәт мәйданнар да юк, Берлиндагы тәмизлек тә юк.* С.Максуди

**ТӘМЛӘНДЕРГЕЧ** *с.* **1.** Өстәмә тәм бирә торган, тәмләндерә торган. *Тәмләндергеч матдәләр*

**2.** *и. мәгъ.* Пешергәндә яки ашаганда, ризыкка өстәмә тәм бирү өчен кушылган, катылган матдә; тәмләткеч. *Майонез – бик нык калорияле ризык. Анда майлар, углеводлар, буягычлар, тәмләндергечләр һәм башка ясалма матдәләр күп.* Файдалы киңәшләр

**ТӘМЛӘНДЕРҮ** *ф.* Тәм бирү, тәмле итү, тәмлегә әйләндерү. *Табынга куелган гәрчич я керән төслерәк: үзе ачы булса да, ризыкны тәмләндерә.* М.Маликова

**Тәмләндерә төшү** Бераз тәмләндерү; тагын да тәмләндерү. *Рабига ханым ризыкны тагы да төрләндерә һәм тәмләндерә төште, ирен юк-бар белән артык йөдәтмәскә, борчымаска тырышты.* Э.Касыймов

**Тәмләндереп җибәрү** Тиз генә тәмләндерү. *Нәрсә әйтергә теләвен аңламасам да, тәнгә җылы йөгерттем дә тәлинкәдәге кыяр кисәге белән авызны тәмләндереп җибәрдем.* Р.Рахман

**ТӘМЛӘНҮ** *ф.* Тәм керү, тәмлегә әйләнү. *Авыз тулы коймак, чәйнәгән саен тәмләнә.* А.Гыйләҗев. *Балан кырау тигәч тәмләнә.* Ш.Галиев. *Хәлвә, хәлвә, дигәннән генә авыз тәмләнми.* А.Хәлим

**Тәмләнә башлау** Тәмләнүе сизелү, беленү. *Ашлары тәмләнә башлаган.* Ә.Шаймәрданов

**Тәмләнә төшү** Бераз тәмләнү; тагын да тәмләнү

**Тәмләнеп китү** Тиз арада тәмләнү. *Өйгә урман исе, табигать исе, сафлык исе кереп тулды, һава хушланып, тәмләнеп китте.* Г.Гыйльманов

**ТӘМЛӘП** *рәв.* 1) Берәр нәрсәне авызга кабып, тәмен билгеләп, татып, авыз итеп

2) Нәрсәнең дә булса тәмен тоеп, тәме белән ләззәтләнеп. *Юл читендәге тукранбаш чәчәгендә --- төклетура тәмләп кенә бал суырып маташа.* Г.Бәширов. *Аннан соң эре тешле карт та бер дә әле сиздерми: этисе белән бергә тәмләп чәй эчәләр.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Берәр нәрсәдән ләззәт табып, рәхәтләнеп, ашыкмыйча, җиренә җиткереп, тиешенчә бәяләп. – *Хатынкызга диплом югарырак кругтан кияү сайлар өчен генә кирәк, – ди торган иде апасы һәм Фазылҗанны ничек итеп «кулга төшерүен» бик тәмләп сөйләргә керешә иде.* Г.Әпсәләмов

**ТӘМЛӘ́П-ТӘМЛӘП** *рәв.* 1) Ризык яки эчемлекнең тәмен белеп, аңлап, ләззәт ала-ала, ләззәтләнеп. *Мәрхәбә дә ширбәткә оста булып чыкты: --- хуҗа хатынның элекке әзерләгәненә караганда тагын да тәмлерәк ясап куйды. Мәҗлестә моңа авыз гына тидерделәр, тәмләп-тәмләп өчәр генә йоттылар.* Г.Ибраһимов

2) *күч. к.* **тәмләп** (*2 мәгъ.*)

**ТӘМЛӘТКЕЧ** *и.* Хуш исле, үзенчәлекле тәмле, ашамлыкка яки эчемлеккә өстәмә тәм төсмере бирү өчен салына торган борыч, дарчин, уылган үсемлек тамырлары һ.б.ш. нәрсә. *Тәмләткечләрне – тоз, борыч, горчица, керән, катык һәм соусны – шулар өчен махсус эшләнгән савытларда бирәләр.* Татар халык ашлары

**ТӘМЛӘТҮ** *ф.* 1) Ризыкка тәмләткечләр салу, махсус рәвештә тәмле итү. *Мәтрүшкә дә салыйммы? Иллә дә тәмләтә инде ул чәйне!* Ш.Маннапов

2) *күч.* Йомшак, ягымлы итү. *Булачак бианасы киленгә бал белән май каптырды, әйтерсең Әмдәзиянең әрем телен шул гына тәмләтә ала!* Н.Көбәш

**Тәмләтә төшү** Беркадәр тәмләтү

**Тәмләтеп алу** Тиз генә тәмләтү. *Халат кесәләренә «авыз тәмләтеп алырсыз» дип алма, апельсин, шоколад, груша ише вак-төякне салсаң да, мәгънәле елмаеп кабул итәләр.* Т.Галиуллин

**Тәмләтеп җибәрү** Тиз арада, өстәмә рәвештә тәмләтү; тәмләнгән хәлгә китерү. *Киңәш: диңгез кәбестәсе, помидор, суган, зәйтүн җимешеннән салат ясагыз да зәйтүн мае белән тәмләтеп җибәрегез.* Сөембикә

**ТӘМЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Берәр ризыкның, эчемлекнең авызга кабып тәмен

билгеләү, авыз итеп тәмен белү; шуңардан авыз итү, татып карау. *Тик шул ук брамат Тәвриз Мөбарәков турында гына: «Коньякларын эчә, икраларын тәмли, --- әмма бәяне куймый», – дип сөйлиләр иде.* Т.Галиуллин. *Бу «затлы нигъмәтне» тәмләгән Мөхәммәт Мәһдиев белән Фәрваз Миңнуллин, җае чыккан саен, әле хәзер дә шаяртып искә төшереп торалар.* Казан утлары

2) Ризыкны төрле тәмләткечләр ярдәмендә тәмле итү, тәм өстәү. *Ашны борыч, бөтнек, дәфнә яфрагы салып тәмләү. Чәйне шикәр салып тәмләү*

**Тәмләп калу** Тәмләргә өлгерү. *Шишкин урманнары һавасын суларга, Чулман, Вятка балыгын тәмләп калырга теләүчеләрнең саны көннән-көн арта бара.* Т.Галиуллин

**Тәмләп карау** Сынау-тикшерү максаты белән нәрсәне дә булса тәмләү. *– Бабагыз бүген яңа бал суыртты, тәмләп карагыз, – дип, боларны чакырып алды.* З.Мурсиев

**ТӘМЛӘ́Ү** II *и.* Кешедә һәм хайваннарда авыз куышлыгының һәм телнең лайлалы тышчасы ярдәмендә барлыкка килгән биш тышкы тойгының берсе; тат, тәм сизү сәләте. *Ишетү, иснәү, тәмләү, капшап карау кебек тою сәләтләре*

**ТӘМЛЕ** *с.* **1.** 1) Нинди дә булса тәме булган, ниндидер тәм килеп торган. *Әче тәмле дару*

2) Ашар, эчәр өчен татлы, ләззәтле. *Күп һәм симез ит белән озак кайнаган бу шулпа бик көчле, бик тәмле, бик туклыклы иде.* Г.Ибраһимов. *– Мин Фатихәттәй белән Мәдинә Идрисовна сиңа бик тәмле мүк җиләге кесәле җибәрделәр, – диде ул, сумкасыннан пыяла банка чыгара-чыгара.* Г.Әпсәләмов

3) Исе әйбәт булган, хуш исле. *Йортның ишеге, хуҗаларның күңеле киңлеген раслап, киерелеп ачылган, моржасыннан, каен тузы янган тәмле ис таратып, юаш кына төтен чыга.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Зур канәгатьләнү хисе, рухи рәхәтлек бирә торган; ләззәтле. *Ашыйсы килми… эчәсем килми. Баштанаяк гыйшык сайрый торган, тege матур, тәмле романнар да туйдырган.* Г.Ибраһимов. *Кичке аштан соң һәркемнең кәеф әйбәт. Куе, тәмле әңгәмә бара.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Күңелгә ятышлы, күңелне йомшартырлык. *Сиңа соң тәмле телемне әрәм итеп торган булам.* Ф.Хөсни. *Директор тугры колын елмаеп, тәмле сүзләр белән коендырып, үз катына чакырып кертте.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәндә, күңелдә ләззәт һәм рәхәтлек тоеп, рәхәтләнеп. *Уятып сорарга кызгандым, бигрәк тәмле йоклый идең.* Н.Әхмәдиев. *Тәмле ашап алсаң, әллә ниләр кылып, майтарып ташлыйсы килә.* Г.Каюмов

**3.** *и. мәгъ.* Ашаганда, эчкәндә ләззәт китерә торган азык. *Өстәлләрдә --- тел белән әйтеп бетерә алмаслык матур, кәрәзләп өелгән, чәчәктәй чәкчәкләр, шулай ук чәчәк кебек матур купшы гөбәдия һәм башка тәмлеләрне санасаң, санау озакка китәчәк.* Б.Рәхимова

◊ **Тәмле телле** Кешеләр белән ягымлы, йомшак итеп сөйләшә белгән. *Мөхәммәтшакир бу мәдрәсә шәкертедәй сәйләндәй тезеп кенә чишелеп тәмле сөйләшүче тапкыр малайны ошатты. Безнең якның кызлары-егетләре бик тәмле телләр.* М.Мәһдиев. **Тәмле телне тәмсезләү** Берәү турында кирәкмәгән, килешмәгән нәрсә сөйләү

**ТӘМЛЕКӘЙ** *и.* 1) Тәм-том, нинди дә булса тәмле, татлы ашамлык. *Үз бакчаларында да хәттин ашкан андый тәмлекәйләр…* Н.Сәйяр. *Бөдрә чәчле, чем кара күзле, түгәрәк йөзле малай, нәни куллары белән өстәл читенә тотынып, аяк очларына баскан да, өстәл өстендәге тәмлекәйләргә түгел, күзләрен алмый Рәмилгә карый иде.* К.Кара

2) *бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан дүрткырлы озын сабагы ашарга яраклы, зәңгәр чәчәкле үлән үсемлек; иенке шалфей. *Сукмак буенда кардан ычкынган былтыргы әрем, тәмлекәй сабаклары баш күтәреп маташалар.* Ә.Еники

**ТӘМЛЕЛӘНҮ** *ф. к.* **тәмләнү**. *Сарык бәрәннәренең әчкелтем тирес исен, яшькелт камыш исе белән кушылып тәмләләнгән исне сулый-сулый ятсаң һәм бик озак итеп йокласаң икән…* Н.Яһудин. *Сыерларның да сөтләре тәмләләнде.* Р.Рахман

**Тәмлеләнә бару** Көннән-көн ныграк тәмлеләнү, тәмлелеге арту. *Гаҗәп икән: үткән саен яшем, Тәмлеләнә бара арышың.* Р.Сәйфетдинов

**Тәмлеләнә төшү** Бераз тәмлеләнү; тагын да тәмлеләнү. *Ә аңа юеш яфрак, ылыс исе кушылгач, ул тагын да тәмлеләнә төшә…* Безнең гәҗит

**Тәмлеләнеп китү** Сизелерлек тәмлеләнү. *Син кайткач, ризыклар тагын да тәмлеләнеп киткән сыман була иде.* Туган як. *Киптерелгән гөмбәдән икенче аш әзерләгәндә, гөмбәне бераз сөттә тотсаң, ул хуш ислерәк була, йомшарып, тәмлеләнеп китә.* Әлмәт таңнары

**ТӘМЛЕЛӘТҮ** *ф. сир. к.* **тәмләндерү**. *Минә монсы – авыз тәмлеләтергә кәмфит.* Г.Камал

**ТӘМЛЕЛЕК** *и.* Билгеле тәмдә булу хәле; тәмле булу үзлеге. *Туган якларында кыр бәрәңгесен алганда, сабакларын җыеп яндырганда, аның төтене шундыйрак саргылт яшел төстә булыр иде, ә исенең тәмлелеге турында әйтеп торасы да юк, хәзер сагынып искә төшерергә генә калды.* М.Хәсәнов. *Чәйнең тәмлелеген әйт син, телеңне йотарсың!* Н.Әхмәдиев

**ТӘМЛЕТАМАК** *и.* Татлы ризыклар, тәм-том ашарга яратучы. *Ябык Мөрәдис кабарынган күркәгә охшаган тәмлетамакларга караганда да гаять ашамсак һәм эчемсәк иде.* Л.Лерон. *Тәмлетамак ул, өчпочмак, пылау, тутырган тавык өчен үлә.* Н.Гыйматдинова

**ТӘМЛЕТАМАКЛАНУ** *ф.* Тәмлетамакка әйләнү, тәмлетамак булып китү. *Бүген, әгәр дә шушы рәвешле тәмлетамаклансам, һәркөнне ризыгыбыз булган, соңгы елларда үзенең тансыклыгын оныттыра башлаган кара икмәккә чират җитмәскә тиеш иде.* Ф.Яхин

**ТӘМЛЕ́-ТАТЛЫ** *с.* 1) *к.* **тәмле-тәмле**. *Карун бай кырларга, яланнарга тәмле-татлы ризыклар да куеп караган.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Күңелгә ятышлы, ягымлы; рәхәт. *Тәмле-татлы хыялларга чумып, романтик квартирасына кайтып җиткәнен сизми дә калды.* Г.Афзал. *Шуңа күрә йокыны гадәти исеме белән генә түгел, тәмле-татлы йокы дип йөртә башлаганнар.* Х.Гайнетдинов

**ТӘМЛЕ́-ТӘМЛЕ** *с.* Берсеннән-берсе тәмле, тәмнәре төрле булган, күп төрдәге. *Өстәл тулы тәмле-тәмле сыйлар иде.* М.Галәү. *Каз үзенең бәпкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыслалар тотып китерә икән.* А.Алиш

**ТӘМЛЕТЕЛ** *и.* Күңелгә ятышлы, ягымлы сүзләр сөйли белүче кеше. *Төрле тәмлетелләргә түгел, үзем күргәнгә күбрәк ышанам*

**ТӘМЛЕТЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Ягымлы, йомшак сүзләр белән сөйләшү. *Тәмлетелләнергә мин бит кызыл утлы йорттагы кәнтәй түгел!..* А.Гыйләҗев

2) Мактау, кыстау һ.б.ш. сүзләрне кирәгеннән артык куллану, төчеләнү, ялагайлану

**ТӘМЛЕТЕЛЛЕЛЕК** *и.* Йомшак сөйләшү гадәте, ягымлы телле булу сыйфаты. *Чөнки үз өйләрендә әниләре һәр эшне йомшаклык, тәмлетеллелек белән җиңә килде.* Ф.Яруллин

**ТӘМЛЕ́-ТОМЛЫ** *с.* **1.** Ашар-эчәр өчен тәмле, ләззәтле. *Тәмле-томлы ашлар көн дә булмый.* Н.Дәүли. *Төенчек эченнән тәмле-томлы нәрсәләр килеп чыкты.* Р.Ахунҗанова

**2.** *и. мәгъ.* Шундый ризыклар. *Хәлле яшәгән Сәбиләнең үзенә тәмле-томлы сузуына да шулай ук карамады.* Т.Гарипова. *Ә без матур итеп кунак булырбыз, фарсылардан килгән тәмле-томлыларны ашарбыз.* М.Хәбибуллин

**ТӘМЛЕ́-ТӨМЛЕ** *с. диал. к.* **тәмле-томлы**. *Шуннан күңелгә бер әйбәт уй килде: әлеге карчык баш тарткан акчаны Һәммәюнгә биреп, шул балаларга тәмле-төмледән ни дә булса, ә карчыкның үзенә чәй-шикәр алып, шуларның һәммәсен киткән чагында гына кулына тоттырырга куштым.* Ә.Еники

**ТӘМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Бернинди тәме булмаган. *Тәмсез матдә. Иссез һәм тәмсез сыеклык*

2) Тәме начар булган, ашаганда, эчкәндә, иснәгәндә ләззәт бирми торган. *Карчык --- әзерләп килгән әрем кайнатмасын көчләп эчерде. Бу – гаҗәп бер тәмсез, әче нәрсә иде.* Г.Ибраһимов. *Ничек ашыйсың син шундый тәмсез нәрсәне?* Ф.Яруллин

3) *күч.* Күңелне кыра, авыр тәэсир итә торган, күңелгә ятышсыз, кимсетүле. *Әгәр син мин белгәннәрне белсәң иде, әгәр син аларның исәпләрендә береккән тәмсез фикерләрне уйласаң иде, --- ул вакыт син аларның йөзләренә лач итеп төкерер идең.* Г.Буби. *Син дә шул тәмсез сүзең белән эчемне пошырмасана!* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Мәгънәсез, ямьсез, буш, рухи канәгатьлек бирми торган. *Дөрес, арада төссез, тәмсез, иләмсез җырлар да ишетелгәли.* Х.Ширмән

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәме күңелгә ятырлык итеп түгел; авызга алгысыз дәрәҗәдә. *– Ризыгыгыз тәмсез пешкән, исраф итүдән артыгын белмисез, бай абзагыз ачуланды, – дип, тиктомалга барысын да орышырга тотынды.* Ф.Яхин. *Шуңа да иптәшләремнең, бакчада тәмсез ашаталар, тары боткасы бирәләр, бакчага барасы килми, дип сөйләүләре бик кызык тоела иде.* Шәһри Казан

◊ **Тәмсез телле** Күңелгә ятышсыз итеп, дорфа сөйләшә торган. *Аның ире – каты күңелле, миһербансыз, тәмсез телле Шиһабетдин – Ижевск шәһәрендә корал заводында эшли иде.* М.Мәһдиев. **Тәмсезгә китү** Аралар, мөнәсәбәтләр начарлану, бозылышу. *Бу кыланышларның ахыры тәмсезгә китеп бармасын.* М.Фәйзи

**ТӘМСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Тәмсез хәлгә килү, тәмсезгә әйләнү, начар тәм алу. *Вакытында өзмәсәң, кызарып пешкән җиләк тә тәмсезләнә.* Ф.Яруллин. *Бу авылны шәһәр йоткан... Ә бәлки, чишмәләренең суы тәмсезләнгәч китеп барганнардыр?* К.Кәримов

2) Тәм тою сәләтен югалту. *Ләкин ул авызының тәмсезләнгәнен тойды һәм бу тәмсез сыекчаны шунда ук төкереп ыргытасы килде, ләкин иптәшләреннән яхшысынмады.* Н.Әхмәдиев

3) *күч.* Теле, сөйләшүе бозылу, ямьсез сүзләр белән сөйләшә башлау. *Ганинең эчүе ешайды, холкы кырысланды, теле тәмсезләнде.* С.Зыялы

4) Авыр сүз әйтеп, килешмәгәнчә кыланып, мөнәсәбәтләрне бозу. *Ул чакта үч саклаган, бер-берсенә хәтере калган кешеләр дә, телгә килешеп, тәмсезләнеп, ямьле көннәрнең ямен җибәрмәгәннәр.* М.Хәсәнов. *Юкка тәмсезләнәсең, хатын-кызга килешә торган түгел.* Э.Яһудин

5) *к.* **тәме китү** (*1 мәгъ.*). *Моңнарының бер тәме юк, Тәмсезләнде дөньялар. Өй турында туктап, бәлки, «Гөлҗамал»ны сузарлар ---.* Р.Идиятуллин

**Тәмсезләнә бару** Торган саен ныграк тәмсезләнү

**Тәмсезләнә башлау** Тәмсезләнү билгеләре сизелү, тәмсезләнүгә йөз тоту. *Вакыт-вакыт тәмам өлгереп, әчеп тәмсезләнә башлаган җиләкләрне ашарга киләләр алар.* Шәһри Казан

**Тәмсезләнә төшү** Бераз тәмсезләнү; тагын да тәмсезләнү. *Башка яшелчәләрдән аермалы буларак, чөгендерне тозлы суда пешермиләр, төсен югалта, һәм тәме дә тәмсезләнә төшә.* Сөембикә

**Тәмсезләнә язу** Чак кына тәмсезләнми калу. *Җилкуар исемен ишеткәч, авыз тәмсезләнә язды.* М.Рафиков

**Тәмсезләнеп бетү** Тәмам тәмсез хәлгә килү, бөтенләй тәмсезләнү. *Мин [балны], бик әчеп, тәмсезләнеп бетмәсен дип, базга төшереп куйган идем.* Г.Камал. *Яшьләр җыелыштан кайтуга, дөге боткасы суынып, тәмсезләнеп беткән иде.* Н.Фәттах

**Тәмсезләнеп йөрү** Гел, еш тәмсезләнү. *Зөлфәтнең безнең йортка килеп тәмсезләнеп йөрүен тыям мин.* А.Гыйләҗев

**Тәмсезләнеп калу** Берәр хәлдән, тәэсирдән соң тәмсезләнгән хәлгә килү. *Гадәттә, хатын-кыз белән булганнан соң, Сәет үзен физик һәм рухи яктан бушап, төссезләнеп, тәмсезләнеп калгандай сизә иде.* Т.Галиуллин

**Тәмсезләнеп китү** Кинәт тәмсезләнү. *Аның авызы тәмсезләнеп китте, каткат төкеренеп куйды.* Казан утлары

**ТӘМСЕЗЛӘТҮ** *ф. к.* **тәмсезләү** (*1 мәгъ.*). *Тәмәкенең авызны бик тәмсезләткәнен --- тойгач, ул аны тартып бетермәде.* Ф.Әмирхан

**ТӘМСЕЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Үз тәмен бозу, юкка чыгару, тәмен алу; тәмсез тәм бирү, тәмсез итү. *Ә бит тормыш – шул ук кое. Һәр тормышның чиста суны тәмсезләп тора торган катламы бар.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Сүз, әңгәмә, мәҗлес һ.б.ларның агышын килешмәгән, күңелгә ятышсыз якка бору, кәефне бозу. *Авызымны тәмсезләп, бүтән бер сүз дә әйтмим бу ике аяклы этләргә, тәкъдиремдә язганы булыр...* Г.Тавлин

3) *күч.* Мөнәсәбәтләрне бозу, үпкәләтү

**Тәмсезләп бетерү** Бөтенесен дә тәмсезләү; тәмам тәмсезләү

**Тәмсезләп кую** Көтмәгәндә, кинәт тәмсезләү. *Мин дә шулай студент булачакмын, дигән тәмле уемны артка чигереп, алда – томаннар аръягында – өч елың бар әле, үзе бер гомер, дигән уй тәмсезләп куя.* М.Галиев

**Тәмсезләп тору** Һәрвакыт, әледәнәле тәмсезләү. *Капитан гомере буе шул яра белән яшәде, шул шөбһә язмыш касәсендә шәрабны гел тәмсезләп торды.* Г.Камал

**Тәмсезләп яту** Тәмсезләү процессында булу; озак вакыт дәвамында тәмсезләү. *Ничәмә еллар рәттән, ничәмә йөзләгән нефть скважиналары грунт, туфрак суларын агулап, чишмәләрне тәмсезләп ятканнар лабаса.* Ә.Маликов

**ТӘМСЕЗЛӘШҮ** *ф. урт. юн.* Кем беләндер араны бозу, үзара талашу, ызгышу, ачуланышу, тиргәшү. *Җитмәсә, кичә вахтага кызмача килде, тәмсезләште, искә төшерергә чирканыч сүзләр әйтеп җанымны мәсхәрәләде.* Җ.Рәхимов. *Кайчак тыелып та калып булмый, кычкырып җибәрәм. Тәмсезләшергә туры килә.* Х.Камалов

**Тәмсезләшә башлау** Тәмсезләшергә тотыну. *Әллә тәмсезләшә башлаганнар инде?* А.Гыйләҗев

**Тәмсезләшеп бетү** Тәмам тәмсезләшү, эш тәмсезләшүгә үк барып җитү. *Әйберләрен басмасалар, үзен аңламауларына, аңа юл бирмәүләренә сылтады, талантны кысалар дип адарынды һәм күпчелек редакция халкы белән тәмсезләшеп бетте.* Ә.Әминев

**Тәмсезләшеп йөрү** Озак вакыт тәмсезләшү. *Сез болай улыгыз белән тәмсезләшеп йөреп, әниегез рәнҗеп ятар дип курыкмыйсызмы?* Безнең гәҗит

**ТӘМСЕЗЛЕК** *и.* 1) Тәме начар булу, тәмсез булу сыйфаты; начар тәм. *Силос дигәннәрен авызга ала торган түгел, димен. Тәмсезлеге генә бер хәл. Исе...* М.Садыйков

2) *күч.* Сүзләрнең, сөйләшү рәвешенең ямьсезлеге, дорфалык, тупаслык. *Телләрендәге тәмсезлек үзеннән-үзе колакны сагайтырга мәҗбүр итте.* Авыл офыклары

3) *күч.* Күңелсез вакыйга, кирәкмәгән, килешмәгән кыланыш, эш-гамәл. *Аның күңеле инде шактый тынычланган, мәҗлестә булып үткән тәмсезлекләр каядыр таралып киткән, күңел түрендә япа-ялгыз булып Фәлинә генә торып калган иде.* Г.Рәхим. *Нинди гаугага, нинди тәмсезлек булган диден син сунарда?* Р.Батулла

**ТӘМСИЛ** *и. гар. иск.* 1) Кемнедер, нәрсәнедер кемгә яки нәрсәгә дә булса охшату, чагыштыру. *Без Думаны моннан мөкаддәм бер номерымызда да шул ике хайван хәленә охшашлы дигән идек, ләкин хәзер безнең бу тәмсилемездә хаклы икәнемезне Зурабов нотыкы тугрысында булган вакыйгалар бигрәк тә ачык күрсәткәнлектән, янә шул тәмсилемезне тәкрарладык.* Г.Тукай

2) Чагыштыруга үрнәк булган әйбер яки зат. *– Берничә сәгатьтә бу кадәр җирләрне сәер итмәк мөмкин түгелдер, – дип, золмәте җәһаләттә калдылар. Бәс, бу бабта берничә тәмсил бардыр.* К.Насыйри

3) *к.* **мәсәл**. *Шуның өчен бу тәмсилне укып чыксаңыз, зарар тапмассыз.* Г.Тукай. *Кечкенә тәмсилем бар, тезеп булса, Тыңларсыз, бәлки, сез дә, кызык булса.* Ш.Бабич

**ТӘМСИ́Л ИТҮ** *ф.* 1) Охшату, нәрсә беләндер тиң күрү

2) Нәрсәнедер гәүдәләндерү, чагылдыру, шуның чагылышы, үрнәге, мисалы, символы булып тору. *Крылов бабайның баснялары, һәрвакыт, һәркемнең кыланышын тәмсил итеп күрсәтер өчен кыяматкә кадәр ярарлык бер көзге, дисәк, ялган түгелдер.* Г.Камал. *Мәсәлән, Я.Экман язганча, бу ядкәр, «кыпчак телен тәмсил иткән әсәрләрнең берседер».* Гасырлар авазы

2) Берәр кеше яки оешма һ.б.ш. исеменнән эш йөртү, шуның вәкиле булып тору, вәкиллек итү. *Олимпия уеннарында илне тәмсил итү*

**ТӘМСИЛЧЕ** *и. иск.* Берәр кеше яки оешма исеменнән эш йөртүче зат; вәкил. *Ленин һәм иптәшләренең Шәрык өлкәләрендә социализм төзү мәсьәләсендә урындагы хезмәт ияләренә һәм җирле социалистларга ышанмаулары, бу өлкәләрдәге җитәкчелекне рус пролетариаты тәмсилчеләренә бирергә теләүләре аңлашылды.* Г.Баттал-Таймас

**ТӘМ-ТОМ** *җый. и.* Төрле тәмле, татлы ашамлыклар. *Кадерле кунак килсә дип саклап тоткан әллә нинди тәмтомнарын өстәлгә тезде.* Р.Мулланурова. *Келәттән алып керелгән бал-май, киптерелгән урман сыйлары, төрле тәм-том белән тулган иде өстәл өсте.* Р.Мөхәммәдиев

**ТӘМУГ** *и.* 1) *дини* Дөньяда гөнаһ кылучылар үлгәннән соң җәза күрәчәк урын; җәһәннәм. *Менә шул малай үзе дә бик эт авыз нәрсә, ди: «Алла да юк, мулла да юк, оҗмах та юк, тәмуг та юк – бары да шып-шыр, тип-тигез», – дип әйтә икән, ди.* Г.Ибраһимов. *Ә менә әнинең әллә ни исе китмәде. «Җитте сезгә, аның каравы остаз суккан җир тәмугта янмый...» – диде әни.* Г.Гобәй

2) *күч.* Физик һәм рухи яктан түзеп булгысыз шартлар, шундый шартлар булган урын. *Куркытмагыз әле тәмуг белән, Тәмугларның иң хәтәре җирдә.* Ф.Зыятдинова. *Тик Сәбилә бу йортка төшәчәк килен өчен борчылудан туктамады. Бала гына бит әле – унҗиде яшь. Чәчкәдәй чагында Гариповлар тәмугына килеп кермәсә булмый микәнни?!* З.Мурсиев

◊ **Тәмуг базы** *к.* **җәһәннәм базы**. *Әйләнчек чире йоккан сарык кебек, шыксыз тәмуг базында ике-өч адым саен борылырга туры килгәнгәме, Иргалинең башы әйләнеп, күңеле болгана башлады.* М.Хәсәнов. **Тәмуг газабы** *к.* **җәһәннәм газабы**. *Бөкләп кенә ташлаячак, тәмуг газапларын күрсәтәчәк.* Ф.Яхин. **Тәмуг кисәве** 1) Һичшиксез тәмугка керергә тиешле гөнаһлы кеше. *– Матчадагы балта эзе антымны һәр көн искә төшереп торсын, әгәр антымны бозсам, Раббым Аллаһым, үзең иң каты җәзаңны бир, миннән тәмуг кисәве яса! – дип әйт.* З.Мурсиев; 2) *тирг.* Гөнаһлы эш эшләүдән тартын-

маган, оятсыз, вөҗдансыз кеше. *Хәзер үк чыгып кит, тәмуг кисәве!* К.Нәҗми. *Тәмуг кисәүләре, телләрегез корып китеп, Алланың каһәренә очраган кяферләр!* Ә.Айдар. **Тәмуг уты** 1) Чыдап булгысыз эсселек; 2) Чыдап булмаслык авыр шартлар; газап, михнәт. *Яшьлегендә өзелеп сөйгән ярларының сүзсез рәшәләреме, --- әллә инде йөрәгендә булган сөю хисен иң каһәрле – сугыш дип аталган тәмуг утының ялмап йотуымы, әллә башка сәбәпләрме, ул күп вакытта хисләрен тышка чыгарырга, хәтта гомер буе дөнья көткән хатыны белән дә уртаклашырга ашыкмады.* Х.Мөдәррисова. **Тәмуг утыны** *гади с. тирг. к.* **тәмуг кисәве** (*2 мәгъ.*). **Тәмуг чукмары** *к.* **тәмуг кисәве**. *Тәмуг чукмары, синең белән гөнаһка батып бетәрсең, тәүбә, тәүбә!* Һ.Такташ

**ТӘМУГЛЫ** *с.* Тәмугка керәсе, тәмуг әһеле булырдай. *«Иманга юл» сәхифәсендә еш кына дин әһелләре --- башка диндәге кешеләр барыбер кяферләр, алар тәмуглы, дигән төшенчәне ассызыклап киләләр.* Безнең гәҗит

**ТӘМУГЛЫК** *с.* **1.** Тәмугка кертерлек гөнаһлы. *Тәмуглык кеше дип, кызганып та алабыз.* Ш.Камал. *Минем инде ни оҗмахлык, ни тәмуглык эшем юк.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Тәмугка керерлек күп гөнаһлы кеше, җәһәннәмлек

**ТӘН** *и. фар.* 1) Кеше яки хайванның бөтен әгъзалары белән берлектәге гәүдәсе; сын, бәдән, җәсәд. *Иртә таңнан караңгы кичкә кадәр берөзлексез йөгереп, чабып, эшләп йончыган, арыган тән шушы тынлыкта акрын гына изри, ойый.* Г.Бәширов. *Бөтен тән: баш та, аяклар да, куллар да, гәүдә дә ут яна.* Р.Вәлиев

2) Җанның физик тышчасы, ул урнашкан матди җисем. *Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән – матур, изге, бөек яшәү белән яшисем килә.* Г.Бәширов. *Юк, мин сезгә, бары тик шул тән өчен тотылган байлыкларның, тырышлыкларның, белемнең беразын гына булса да җан өчен тотсак, күпме исәпләп бетермәслек файда булыр иде, диюем генә...* Г.Каюмов

3) Гәүдәдәге ит, мускул катламы. *Йомарлам май сыман тыгыз тән, егет кочагына керүгә, башта ничектер калтыранып куйды һәм шундук эреп, таралып төште...* Р.Мөхәммәдиев. *Сулыш алырга тырышкан саен, тимерчыбыкның очлы тешләре аның тәненә тагын да тирәнрәк кадала бара.* А.Хәсәнов

4) Гәүдәдәге ит, мускул өслеген тышкы яктан әйләндереп алган катлам; тире. --- *кояш нурларын мул сеңдергән тән, шоколад исе аңкып торган куе, аксыл сары чәчләр, зифа гәүдә, төз аяклар...* Д.Гыйсметдин. *Бәләкәй генә борын, уймак ияк, ярым ачык тулы иреннәр, ефәк төсле шома тән – Ходай Тәгалә тудырган гүзәллеккә таң калырлык, күреп туймаслык.* К.Кара

5) *күч.* Агачларның, үсемлекләрнең кабык астындагы катламы; үзагач. *Пар нарат бөтенләй корып бетә язган, --- кабыклары да кубып, карт тәннәре шәрәләнеп калган.* Г.Бәширов

6) *күч.* Кабык үзе. *Вакытлар узу белән, чыршы тәнендәге җәрәхәтләр төзәлә.* Г.Гыйльманов

◊ **Тән ватылу** Физик ару, талчыгу, йончу. *Юлда тән ватылып килү үзен сиздерә иде әле, ашаганнан соң, күзләр йомыла башлады.* К.Кара. **Тәнгә йокмау** Ашаса да көрәймәү, симермәү (терлек тур.); тазармау, тулыланмау (кеше тур.). *– Әнә кабыргалары бармак белән санарлык, ашаганы тәненә йокмый, төртсәң аварга тора, – дип, кырыкмышны хурларга тотынды.* А.Хәсәнов. **Тәнгә салкын су сипкән кебек** Кинәт авыр тәэсир итеп, курку, оялу һ.б.ш. хис барлыкка китереп. --- *сүз кайнар тәнгә салкын су сипкән кебек тәэсир итсә дә, сиздермим. Эчемнән, гөнаһлану кемнән калмаган да, без кемнән ким, дип куям.* Р.Рахман. **Тәнгә яту** Килешеп тору, килешле булу. *Тәнемә ятып торган бу күлмәгем әле дә сандыкта саклана.* М.Яһудин. **Тән кабыгы** Җан, рух, йөрәк, күңелдән аермалы буларак кешенең физик гәүдәсе, бәдән. *– Белмим инде, Рахил, – дип сөйли аның тән кабыгы, – башым буталды хәзер. Яратуын яратмыйм инде мин аны, үзең күреп торасың ич, яратырлык җире бармы?* К.Кара. **Тән куну** Көрәю, симерү (терлек тур.); тазару, тулылану (кеше тур.). *Көзгә таба, тән кунгачрак апкилсәң, килере күбрәк булырые, ә болай баш урынына баш алырлык акча җыя алырсың микән?* В.Нуруллин. **Тән куырылу** Берәр тышкы тәэсирдән бөрешеп килү, кузгала алмаслык халәттә тору. *Тиленең карашыннан тән куырыла иде.* Н.Гыйматдинова. **Тән кую** Ашау-эчү җитмәүдән яки авырудан ябыгу. *[Хәмит:] Кулдан килгәнчә тырышырмын, якташ. Ничек тә тән куярга ирек бирмәм...* М.Хәсәнов. **Тән салу** *к.* **тән кую**. **Тән сату** Фахишәлекне кәсеп итү. *Алыпсатарлар берне бишкә арттырып саталар, карак чиновниклар дәүләтне савалар, бизнесменнар надан халыкның эшләгәнен ашыйлар, бандитлар көпәкөндез кычкыртып талыйлар, фахишәләр тән сатып байлык җыялар.* К.Кара. **Тән чымырдау** Тәндә җиңелчә калтырау тою, тән буйлап салкын йөгерү. **Тән язу** Физик эш эшләп яки хәрәкәтләнеп, гәүдәнең оешканлыгын бетерү, гәүдәгә сыгылмалылык өстәү. *Ә Пётр патша үзе инде күптән аягына күтәрелгән һәм ул хәтта, --- кулына көрәк һәм кәйлә тотып, тән язып алырга да өлгергән иде.* В.Имамов

**ТӘНАВЕ́Л ИТҮ** *ф. иск.* Авыз итү, ашап, татып, кабып карау, тәмен белү. *Пылау өләшүчеләр, эшне бетереп, --- урыннарына утырыштылар, тирләппешеп чыккан Сабирҗан мәзин --- һәркемгә ишетелерлек итеп: – Булды, җәмәгать, тәнавел итегез! – дип кычкырды.* М.Галәү

**ТӘНАВЕ́Л КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәнавел итү**. *Сахабәләр ризыкны тәнавел кылдылар.* Мәхмүд әл-Болгари. *Иң әүвәле бал-май китерәләр, кияү белән кәләш шул бал-майдан тәнавел кыйлалар.* К.Насыйри

**ТӘНӘЗЗЕЛ** *и. гар. иск.* 1) Кечекүңеллелек, кечелек, түбәнчелек. *Шул сәбәпле бу рисаләләрнең берсен алып укырга тәнәззел боерган мөхтәрәм кариэләремнән икенчесен дә әлдә итмәкләрене үтенер идем.* Г.Тукай

2) Кимсетелеш, хурлык. *Юк! Кабул итмәс тәнәззелне боларга изге җан!* Гыйффәт туташ

**ТӘНӘЗЗЕ́Л ИТҮ** *ф. иск.* 1) Төшү, түбәнләнү. *Ләкин соңрак заманнарда Зәйнүш абыстайның яшь вакытлары үтеп, һиммәте азайды, куәте тәнәззел идеп, шөһрәте дә кимеде.* Р.Фәхреддин

2) Кечекүңеллелек күрсәтү, түбәнчелек итү. *Кыйнавыма соңыннан үкенеп тә, гафу үтенергә тәнәззел итмәгән идем.* М.Фәйзи

3) Үз дәрәҗәсен төшерү, үз-үзен түбәнсетү. *Сабир мулла гаять голулектә улып, берәр-икешәр генә кичлек хатыннарны, бер аергач, кайтарып сөйләмәгә вә телгә алмага тәнәззел итмәс иде.* Г.Камал. *Бер-берсен чын күңелдән сөешкән, бер-берсе өчен җан бирергә әзер булган ике яшь күңелне бер-берсеннән аеру кадәр рәхимсезлеккә тәнәззел итүеңә сәбәп ни?..* М.Фәйзи

4) Кабахәтләнү, түбәнлеккә, кабахәтлеккә төшү, мораль яктан түбән төшү. *Менә ни дәрәҗәгә хәтле тәнәззел итә ала кеше... Хайваннан да түбән...* Ф.Әмирхан

**ТӘНӘЗЗЕ́Л КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәнәззел итү**. *Олы башыгызны кече итеп, без фәкыйрегезгә җавап бирергә тәнәззел кылуыгыз өчен самиманә рәхмәтләремне вә гаҗизанә тәшәккерләремне кабул боерсагыз иде.* Ф.Гыймалетдинов

**ТӘНӘЙТҮ** *ф.* 1) *бор.* Көч җыярга, көч тупларга, күп көч сарыф иткәннән соң хәл алырга мөмкинлек бирү; көченә, элекке әйбәт хәленә кайтару. *Атны ял иттереп тәнәйтү. Җирне иген чәчмичә тәнәйтүгә калдыру*

2) *неол.* Торгызу, реконструкцияләү. *Бу гына да түгел, бу морфологик законлыкны истә тотып, татар телендә онытылган фигыльләрне тәнәйтергә дә мөмкин.* Р.Әхмәтьянов

**ТӘНӘКӘ** *и.* 1) *бор.* Патша кызы, ханәкә; хан затыннан булган хатын-кыз. – *Без сине, [Гәүһәршад] тәнәкә, Мәскәүдә көтәбез, анагыз Нурсолтан ханбикәгә күрсәтелгән дәрәҗәдә хөрмәтләрбез,* – *дип, кенәз саубуллашырга ашыкты.* М.Әмирханов

2) *күч.* Төпчек кыз. *Мин аның кызы Гөлгенәдән бер атнага кечерәк булгач, ул миңа «тәнәкә», ягъни төпчек кыз, ди иде.* К.Булатова

**ТӘНӘФЕС** *и. гар.* 1) *иск.* Сулыш, тын алу гамәле. *Бакчачылар, үләннәр, чәчәкләр арасында йөреп, саф һава тәнәфес иттекләреннән сәламәт булалар.* Г.Рафикый

2) Берәр тамаша яки нинди дә булса эш барышында бераз ял итеп алу, төп шөгыльдән вакытлыча тукталыш. *Шуңа күрә, симпозиум эшендә төшке ашка тәнәфес игълан ителүгә, мин юлдашларым белән, уңайлы форсаттан файдаланып, урамга ашыктым.* И.Диндаров // Шул тукталып торган арадагы вакыт. *Алгы рәттәге агайларның кайберсе [спектакль барганда] тәнәфестә үк чыгып сызган иде, хәзер тагы берничәсе, ютәлләштергән булып я авыртмаган эчләрен тотып, ишеккә юнәлде.* А.Тимергалин

3) Мәктәптә, уку йортларында бер дәрестән икенчесенә күчкәндә ял һәм әзерлек өчен бирелгән вакыт арасы. *Озын тәнәфестә тугызынчы сыйныф малайлары Айратны уратып алды, һәм төрле яклап киңәшләр ява башлады.* А.Гыймадиев

4) Нинди дә булса гадәтләнгән яшәештән, эшчәнлектән яки шөгыльдән өзеклек, тукталыш. *Өч еллык тәнәфес нәрсә ул?* Г.Сафин

**ТӘНБИҺ** *и. гар. иск.* Кисәтү, искәртмә; искә төшерү, хәтердә яңарту, кабат зиһенгә салу. *Бу мәсәл нәфес явызлыгыннан сакланмага тәнбиһтер.* К.Насыйри. --- *беркөнне мәчеткә кергәч, халыкларның тарау утыруларын күреп, бергә җыелышып утырулары хакында тәнбиһ ясаган иде.* Р.Фәхреддин

**ТӘНБИ́Һ ИТҮ** *ф. иск.* Кисәтү ясау, искәртү, искә төшерү, хәтердә яңарту, уяту. *Кеше үз вазифасын үзе белергә, берәр кеше тарафыннан тәнбиһ итүне көтеп тормаска тиеш.* Р.Фәхреддин

**ТӘНБИ́Һ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәнбиһ итү**. – *Кемнең ишегендә зәгъфран белән бармак эзләре күрсәң, йорт иясе кем булса да булсын, тотып китер,* – *дип, гаять тәнбиһ кыйлды вә кемне тотып китерерләр дип көтеп торды.* К.Насыйри

**ТӘНБИҺЛЕ** *с. иск. кит.* Кисәтүле, искәртүле. *«Нигә әле болар бүген, агымга каршы барып, чека турында язалар?» дигән тәнбиһле сорауларга фаҗигале өченче китап җавап бирергә тиеш иде.* Л.Гарипова

**ТӘНВИН** *и. гар. лингв.* Гарәп язуында исемнәрнең һәм сыйфатларның соңгы сузыгына *-ан//-ән, -ыйн//-ин* яки *-ун//-үн* иҗекләре кушылып укырга тиешлекне күрсәтә торган хәрәкә. *Сәлам бирү «әссәламегаләйкем», «сәлам (тәнвин белән) галәйкем», «әссәлам галәйк», «сәламгаләйк» кебек җөмләләр белән табыладыр.* А.Тимергалин

**ТӘНДӘ** *рәв.* 1) Исән-сау, саусәламәт (кешеләр тур.) – *Хаҗи бабай тәнендәме?* – *Атакай әле зарланмый.* Г.Әпсәләмов

2) Таза, көр (терлек-туар, хайваннар тур.). *Ә атны тәндә тотар өчен, солы сатып алырга кирәк.* В.Нуруллин

**ТӘ́Н ҖӘЗАСЫ** *и. иск.* Россиядә 1903 елга кадәр кулланылган, гаепле дип табылган кешеләрне физик авыртуларга дучар итүдән гыйбарәт җәза бирү төре (чыбык белән суктыру, камчы белән кыйнау һ.б.). *[Мәхәлләдә] Җибәрелгән гаеп эшләр өчен еш кына тән җәзасы кулланылган, аны мулла сайлап алган авыл кешеләре башкарган.* Р.Маликов

**ТӘ́НҖЫЛЫТКЫЧ** *и.* Эченә мамык салып сырылган кыска тышкы кием. *Хәйбүш бабай бишмәте астыннан мех эчле җиңсез тәнҗылыткыч кигән.* Г.Әпсәләмов

**ТӘНКӘР** *и. гар. иск.* Сайлау, сайлап алу; конкурс; элеккеге мәдрәсәләрдә кабул итү имтиханы. *XIX–XX гасырларда Казан мәдрәсәләрендә тәнкәр уздырыла торган булган.* Р.Әхмәтьянов

**ТӘНКӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тикшереп, сайлап алу, конкурс оештыру

2) *диал.* Талымлау, сайлану

**ТӘНКИСӘР** *и. бот.* Субуярлар семьялыгыннан ябык сулыкларда һәм тын елга суларында үсә торган, калын озынча киң яфракларының кырыйларында үткен киртләчләре булган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **телорез**. *Тәнкисәр, су астында сабакларына углекислый газ туплаганнан соң, су өстенә калкып чыга, ә кояшта газы таралгач, яңадан су төбенә чума.* Ботаника

**ТӘНКЫЙДИ** *с. гар.* Тәнкыйтьтән торган, тәнкыйть иткән; тәнкыйтьчел,

критик. *Шундагы язмаларның иң зурысы, кем әйтмешли, сөлге кадәресе, бер язучыбызның тәнкыйди мәкаләсе икән.* Ф.Баттал

**ТӘНКЫЙТЬ** *и. гар.* 1) Берәр эш яки эшчәнлекнең кимчелекләрен, житешсезлекләрен күрсәтү, дәлилләр белән нигезләп әйтү, кисәтү гамәле. *Башкалар әйткәнне колагына алмый, ә инде үзенә карата чак кына тәнкыйть сүзе әйтүчеләрне дошман күрә, аларга ничек тә берәр явызлык эшләмичә калмый торган иде.* В.Нуруллин. *Тәнкыйть бит ул сиңа сыра да, шербәт тә түгел.* Д.Гыйсметдин

2) Фәнни, сәяси, матур әдәбият, сәхнә һ.б. әсәрләрне тикшерү, аларның уңай һәм кимчелекле якларын ачу белән шөгыльләнә торган махсус әдәби жанр. *Проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть, халык авыз иҗаты һәм башкалар – бу әле бер әдәбият кына.* Р.Газиз. *[Ренат абый] Казанга күчеп килгәч, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә башлый: китапларга рецензияләр яза; хикәяләре, мәзәкләре, юморескалары басыла.* Т.Нәҗмиев

3) Шул жанрда язылган хезмәт. *Үзем турында язылган тәнкыйтьләрне, нәрсә язалар икән дип, настроением һәйбәт булганда гына укыйм.* Һ.Такташ. *Язучыларның бер-берсенең әсәрләрен укып тәнкыйть язу эше дә тукталды хәзер.* М.Хәбетдинова

◊ **Тәнкыйть күзе** Игътибарны кимчелекләр эзләүгә юнәлтү. *Ул бичара башындагы, кашындагы, артындагы һәрнәрсәгә, һәр төккә тәнкыйть күзе белән карый башлый.* Р.Газиз. **Тәнкыйтьтән өстен** Бернинди дә кимчелеге юк, үтә төгәл, камил. *Үзләрен тәнкыйтьтән өстен санап йөргән тәкәббер түрәләрнең кикрикләрен шәлперәйтү иде бу.* Ә.Моталлапов. **Тәнкыйтьтән түбән** Иң аз, иң түбән таләпләргә дә туры килми торган, игътибар итәргә дә кирәге булмаган. *Ә бу әсәр хәтта үзешчән түгәрәк күзлегеннән чыгып караганда да тәнкыйтьтән түбән тора.* М.Җәлил. **Тәнкыйть угы** Тәнкыйть сүзләре. *Укучылар газета чыгаралар, андагы тәнкыйть угы кемгә генә кадалмый?!* Р.Газиз

**ТӘНКЫ́ЙТЬ ИТҮ** *ф.* Берәр эшнең, эшчәнлекнең кимчелекле, тискәре якларын, җитешсезлекләрен күрсәтү; тәнкыйтьләү. *Югославиягә качкан барон Врангель дә, Парижга шылган Вакытлы хөкүмәт министры Милюков белән генерал Деникин да безнең Харбиндагы Себер хөкүмәтен тәнкыйть итеп чыккан.* В.Имамов

**ТӘНКЫ́ЙТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **тәнкыйть итү**. *Шуның өчен безнең татар тормышында бик күп очрый торган --- күп хатын алуны үземнең шул вакыттагы ноктаи нәзарымнан тәнкыйть кылып, шуның һәр тарафыннан караганда да өйләнүчеләр өчен дә зарарлы идеken күрсәткән идем.* Г.Исхакый

**ТӘНКЫЙТЬЛӘ́Ү** *ф. к.* **тәнкыйть итү**. *Шахталарны ябуларын тәнкыйтьләп, мин газеталарга, телевидениегә бик күп интервьюлар биргән идем.* З.Хәким

**Тәнкыйтьләп алу** Бераз, берникадәр тәнкыйтьләү. *Алардан азрак көлеп тә, тәнкыйтьләп тә алдылар.* Г.Шәйхетдин

**Тәнкыйтьләп ату** *к.* **тәнкыйтьләп ташлау**. *Мәсәлән, кемнедер артык тәнкыйтьләп атырлар да, минем иҗатым аларга инде ошамый, нәрсәгә миңа иҗат итәргә дип, язуны ташларга мөмкин.* Р.Исхакый

**Тәнкыйтьләп бару** Һәрберсен, булган берсен тәнкыйтьләү. *Һәрбер җөмләне синтаксис, стилистика ноктасыннан тәнкыйтьләп барырга була.* Л.Әбүдәрова

**Тәнкыйтьләп бетерү** Бик нык тәнкыйтьләү

**Тәнкыйтьләп йөрү** Һәрвакыт һәм бөтен җирдә тәнкыйтьләү. *Заманында митингларда, җыелышларда, гомумән, теләсә кайда хөкүмәтне, депутатларны, президентны тиргәп, тәнкыйтьләп йөргән берничә кешене беләм мин.* Р.Миңнуллин

**Тәнкыйтьләп карау** Тәнкыйтьләргә омтылыш ясау. *«Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре»ндә берәр шәхесне тәнкыйтьләп кара әле син...* Н.Алан

**Тәнкыйтьләп килү** Күптәннән, электән үк, даими рәвештә тәнкыйтьләү. *Шунысы гына бераз гаҗәпләндерә: Бердыевны моңа кадәр гел тәнкыйтьләп килгән җанатарларның, футбол белгечләренең бер өлеше отставкадан соң остазны яклаучылар сафына басты.* Шәһри Казан

**Тәнкыйтьләп китү** Рәттән, берочтан барысын да тәнкыйтьләү. *Әзһәр абый монда җитәкчеләрне дә, режиссёрларны да, драматургларны да тәнкыйтьләп китте.* Р.Батулла

**Тәнкыйтьләп ташлау** Бик нык, пыран-заран китереп тәнкыйтьләү. *--- артыграк тәнкыйтьләп ташладым мин аны бүген.* Н.Фәттах. *Белоруссия президенты А.Лукашенко Германия газетасына биргән интервьюында янәдән Русияне тәнкыйтьләп ташлады.* Татарстан яшьләре

**Тәнкыйтьләп тору** Һәрвакыт, гел, даими рәвештә тәнкыйтьләү. *Алай гына ерак китеп булса, мин үземне гел тәнкыйтьләп торыр идем.* В.Нуруллин. *Җитмәсә, адым саен кисәтү ясап, тәнкыйтьләп тора иде.* Р.Габделхакова

**Тәнкыйтьләп утыру** Әле, хәзерге вакытта тәнкыйтьләү. *Ренат Харис татар эстрадасын тәнкыйтьләп утыра.* Р.Миңнуллин

**Тәнкыйтьләп узу** Сүз уңаенда, беррәттән тәнкыйтьләү. *Татарстан мәгариф министры әлеге районнар турында хәбәр биреп, аларны тәнкыйтьләп узды.* Р.Әхмәтвәлиева

**Тәнкыйтьләп үтү** *к.* **тәнкыйтьләп узу**. *Дәресләкләр дә җитешми, шул ук вакытта укытучы программада бик авыр әсәрләр булуын да тәнкыйтьләп үтте.* Х.Гайфуллина. *Дамир Исхаков алга таба Татарстан парламентчыларының язу мәсьәләсендә ныклы бер карарга ия булмауларын тәнкыйтьләп үтте.* Татарстан яшьләре

**Тәнкыйтьләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тәнкыйтьләү; тәнкыйтьләп чыгыш ясау. *Бер мәҗлестә өлкән яшьтәге бер керәшен апасы хәзерге керәшен ансамбльләренең урысча такмакларны татарчага борып җырлау белән мавыгуларын тәнкыйтьләп чыкты һәм: «Чын керәшен җыруы менә болайрак була ул!» – дип, озын, борынгы көйне сузып җибәрде.* Р.Шәяхмәтова

**Тәнкыйтьли башлау** Тәнкыйтьләргә керешү. *Соңгы елларда яшьләр мине*

*әсәрләремдә Ленинны уңай сыйфатлары белән телгә алган өчен тәнкыйтьли башладылар*. М.Мәһдиев. *Әгәр кызлар берәр егет белән танышса, тавышы калын, буе озын, чәче кара һ.б. сыйфатларын тәнкыйтьли башлый, үз идеалына туры килми дигән нәтиҗә ясый*. Н.Садыйкова

**ТӘНКЫЙТЬЧӘН** *с. к.* **тәнкыйтьчел**. *[Яшүсмерләрнең] Күбесе кәефсез йөри, --- һәрвакыт нәрсәдәндер зарлана, кирәгеннән артык тәнкыйтьчән, пассив кешегә әйләнә.* С.Сәйфи

**ТӘНКЫЙТЬЧЕ** *и.* 1) Җитешсезлекләрне, кимчелекләрне күрсәтеп, берәр эш яки эшчәнлеккә бәя бирүче, тәнкыйтьләүче кеше. *Дәрәҗәле тәнкыйтьчеләр, дәррәү күтәрелеп, Хәйдәр Әлим өстенә ябырылдылар, аны яклаучыларны да чагып бетерделәр.* А.Тимергалин. *Зиннур Мансуровның: «...һәрбер иҗатчының күңелендә тәнкыйтьче утырырга тиеш. Бары шул очракта гына «тузга язмаганнар» кими төшәр», – дигән сүзләре белән килешмәүчеләр табылмас, дип уйлыйм.* Г.Тарханова

2) Әдәби, фәнни һ.б.ш. тәнкыйть белән шөгыльләнүче белгеч. *Габдрахман Сәгъди – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор.* М.Җәлил. *Ул [Ф.Әмирхан] Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк татар мәдәниятенең үсешен тирән кызыксыну белән күзәтеп килгән, аңа гуманистик караштан чыгып әледән-әле юнәлеш биреп торган зур тәнкыйтьче, җәмәгать хадиме, телче, педагог булып та таныла...* Р.Әмирхан

**ТӘНКЫЙТЬЧЕЛ** *с.* Тәнкыйтьтән торган, тәнкыйть белән караган. *Рәфис әнә – бертуктаусыз теленә салынуда, Шәһит – тәнкыйтьчел күзәтче кебек, композитор Фәһим тыңлап, анализлап утыра шикелле.* Р.Рахман. *Гади генә челтәрләрдән, вак яшькелт бизәкле пәрдәләрдән, --- төсе уңа төшкән карават япмаларыннан тәнкыйтьчел, нәфесле күз бер кер, бер чүп, бер тузан тапмыйча, ниһаять, тынычланып кала.* Д.Булатова

**ТӘНКЫЙТЬЧЕЛЕК** *и.* Тәнкыйтьче шөгыле, тәнкыйть белән бәйле эшчәнлек. *К.Нәҗми, Ш.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов әсәрләрен өйрәнүдән башланган тәнкыйтьчелек эшчәнлегем мине Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Ә.Баянов, Н.Фәттах, Ш.Бикчурин, М.Хәбибуллин, М.Мәһдиев, М.Маликова, А.Расих, М.Хәсәнов, Р.Кәрами һәм башкаларның иҗатын өйрәнүгә китерде.* Ф.Галимуллин. *Хатиповның өченче курста ук шул журналда башланган тәнкыйтьчелек эшчәнлеге гомерле була.* Ә.Дусайлы

**ТӘНКЫЙТЬЧЕЛЛЕК** *и.* Тәнкыйтьчел булу. *Рецензияләрне яңадан бер тапкыр укып чык, үзеңә карата тәнкыйтьчеллек калталарыңны бушатып өстәлеңә сал һәм эшкә [кереш]!* А.Расих

**ТӘНЛӘНҮ** *ф.* Тазару, тулылану, гәүдәгә ит куну; көрәю, симерү

**Тәнләнә бару** Акрынлап, аз-азлап тәнләнү

**Тәнләнә башлау** Тәнләнгәне сизелерлек булу

**Тәнләнә төшү** Аз гына тәнләнү

**Тәнләнеп килү** Аз-азлап, акрынлап тәнләнү

**Тәнләнеп китү** Бераз, берникадәр тәнләнү. *[Терлекләр] Рәхәтләнәләр генә, берничә көн эчендә тәнләнеп китәләр.* К.Тинчурин

**ТӘНЛЕ** *с.* 1) Алдында килгән сыйфат белән тәннең шул сыйфатка ия булуын белдерә. *Җарияләрнең кайсысы ап-ак тәнле, аккош кебек чиста.* В.Имамов. *Төптән юан, уртача буйлы, тыгыз тәнле бу егет Мәнвияне бөтенләй сихерләгән, дөресрәге, кыз үзе сихерләнгән иде.* Р.Кәрами

2) Таза мускуллы, нык бәдәнле; итләч. *Чанага, әлбәттә, тройка җигелмәгән, нибары бер алаша. Ләкин тәнле ат, ярыйсы гына юырта.* Ф.Хөсни

**ТӘНСАКЧЫ** *и.* Кемнең дә булса иминлеген саклау өчен ялланган, аны озатып йөрүче физик әзерлекле кеше. *Фәтхулла хәзрәт мәчеттән чыгып киткәндә, Ишбулдин белән аның тәнсакчысы диварда ремонт вакытыннан бирле тырпаеп торган ике тимер чөйгә якаларыннан эленмеш хәлдә калдылар.* А.Тимергалин. *[Морза:] Тәнсакчыларына күрсәтеп: – Минем бөтен җир дә күзәтү астында, кош та үтә алмый.* Г.Каюмов

**ТӘНТӘРБИЯ** *и.* Тәнне чыныктыру максаты белән үтәлгән спорт уеннары, физик күнегүләр; физик культура

**ТӘНТЕРӘК** *с. диал.* Хәлсезлектән буыннары йомшаган, мәлҗерәгән. *Тәнтерәк карт-коры*

**ТӘНТЕРӘКЛӘ́Ү** *ф. диал.* Тәнтерәк булу, тез буыннары йомшару, хәлсезләнү. *Яшь организм бирешмәс әле. Тәнтерәкләгән карт бабай түгел лә.* Г.Яруллин

**ТӘНТЕРӘ́Ү** *ф. диал.* Алпан-тилпән килеп йөрү, чайкалу; мәлҗерәү. *Башы әйләнүдән тәнтерәп йөрү*

**ТӘНЧЕК** *и. биол.* Тере тән тукымасы составындагы күзәнәк яки күзәнәк эчендәге кисәкчек. *Массаж ясагач, лимфа кисәкчекләре һәм кан тәнчекләре тизрәк хәрәкәтләнә башлый.* Сөембикә. *Тавык шулпасы кандагы ак тәнчекләрнең саклагыч үзлекләрен яхшырта, ә алары исә инфекция белән яхшы көрәшә.* Шәһри Казан

**ТӘҢГӘЛ** *с.* **1.** 1) Бер-беренә тулысынча охшаган, бөтенләй туры килгән, тигез булган, бердәй. *Дүртәр ритмик буыннан торган шигырь юллары тәңгәл булмаган өчәр буын булып яңгырый.* Н.Хисамов. *Тәңгәл почмаклар*

2) Ярашлы, таман; кемгә яки нәрсәгә дә булса туры килерлек; урынлы, килешле. *Монысының тавышы йомшак тенор, әйткәнемчә, гәүдәсенә тәңгәл.* Г.Гомәр. *Бу җирлектән аның хөррият заманына тәңгәл, күтәренке, оптимистик рух белән гади бәндә акылы җитмәслек эшкә алынган, шул эшкә ихлас, фидакарьләрчә бирелгән бер кеше булганлыгы ачык сиземләнә.* М.Гайнетдинов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Билгеле урын, җир, тирәлек. --- *Кунакларга: «Ашкадарны карап китмибезме?» – дидем, чөнки Ашкадарның бу урыннан ерак түгеллеген дә, аның бу тәңгәлдә матурлыгы сакланганлыгын да беләм.* С.Сафуанов. *Инеш зур елгага койган тәңгәлдә эчләренә ком тулып, яртылаш җиргә күмелгән, яртылаш вә тәмамән җимерек көймәләр, алар тирәсендә язгы ташуларда котырган инешнең әллә кайлардан агызып алып килеп өйгән чүп-чар --- өемнәре аша сикерә-атлый, тауга юнәлделәр.* А.Хәлим

2) Ян, як, тирә, туры. *Аның маңгай агыннан өстәрәк тәңгәлдә баш сөяге җимерелгән булган.* А.Хәлим

3) *диал.* Үзән, уйсу урын. *Тәңгәлләрдә, аланнарда зәңгәр күлләр булып кар сулары җыелган.* Г.Әпсәләмов

**3.** *рәв. мәгъ.* Бер-берсенә туры килерлек итеп, бердәй. *Ул үзенең иңбашында Зинаның кулы бик ипле урнашуын, әйләнгәндә һәм йөргәндә, икесенең дә аяклары тигез һәм тәңгәл атлавын, үзенең сул учында Зинаның биле бик тә нәзакәтле ятуын сизде.* Г.Рәхим

◊ **Тәңгәленә туры килү** *диал. к.* **өстенә басу**. *Китсәнә инде! Монысы нәкъ тәңгәленә туры килер дип уйлаган идем бит, әкият!* Ш.Камал

**ТӘҢГӘЛДӘ** *бәйл. к.* **тәңгәлендә**. *Бу тәңгәлдә мин ялгызак түгел, Чал табигать – тиңсез көндәшче ---.* Р.Идиятуллин

**ТӘҢГӘЛЕ** *бәйл. к.* **тәңгәлендә**. *Чөнки язмышыбызга тап булган Тукай урамының Солтан мәчете тәңгәле коточкыч пычрак-чүпле иде.* Шәһри Казан

**ТӘҢГӘЛЕНӘ** *бәйл. к.* **тәңгәлендә**. *Бәгърем белә: чокыр тирәнлеге кендек тәңгәленә җитсә, шул җитә.* А.Хәлим. *Усман карт яшәгән йорт бакчасы тәңгәленә килеп җитүгә, әзмәвердәй гәүдәле ир-егет гөрселдәп рәшәткәгә бәрелде, аннары дөнья яңгыратып бер сүгенде.* А.Хәйретдинова

**ТӘҢГӘЛЕНДӘ** *бәйл.* 1) Нәрсәнең дә булса янында, тирәсендә. --- *җыерчыклы бугаз төере тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен гүяки үз тәнеңне кайрак белән кайрау, телеңне аркылы тешләп, тау чарлагындагы җиз үлән, кылган кыру кебек авыр эшләрнең берсе иде.* А.Хәлим. *Арт урамның уртасы тәңгәлендә, көнчыгышка карап, авызы яхшы ук зур чиләкнеке хәтле булып, бик зур чишмә чыгып ята.* З.Зәйнуллин

2) Берәр нәрсә турысында, мәсьәләсендә. *Утырышта алга таба чыгыш ясаучылар Башкортстанда һәм башка милли төбәкләрдә татар милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү тәңгәлендәге көнүзәк проблемаларга тукталды һәм аларны хәл итү юлларын тәкъдим итте.* Казан утлары

**ТӘҢГӘ́Л КИЛҮ** *ф.* 1) Бердәй, бертигез булу. *Саннары тәңгәл килү белән бәйле.* Ф.Яхин. *Яхшы тегелгән костюм кебек: үлчәмнәре тәңгәл килсә генә әйбәт нәтиҗә бирә.* К.Сатиев

2) Берәр мәсьәләдә, билгеләрдә һ.б.ш.ларда теге яки бу яклары, сыйфатлары белән бердәй булу, бер-берсенә тиң килү. *Талант иясенең идеаллары бүгенге көн обывательләренең таләпләре белән тәңгәл килә алмый.* А.Гыйләҗев. *Медицина белән дә шулай: авыру кешенең рухи омтылышы, теләге врачның рухи омтылышы, теләге белән тәңгәл килеп, гармониягә керә алса гына ул савыга, терелә...* Г.Гыйльманов

3) *мат.* Берсен икенчесенең өстенә куйганда, бер-берен тулысынча каплау, бердәй, бертигез булу (сызыклар, фигуралар һ.б.ш. тур.). *Турылар тәңгәл килә.* Алгебра. *Әмма кәгазьдәге култамгалар тәрәзәдә калган сызыкларга тәңгәл килмәгән.* Ватаным Татарстан

**ТӘҢГӘЛЛЕК** *и.* Бердәйлек, тиңдәшлек; бердәй булу, бер дәрәҗәдә булу хәле. --- *ихлас күңелдән алып барылган әңгәмә, тәңгәллек, иптәшеңне аңлый һәм тыңлый белү һәртөрле ясалма «артистлар»ны алмаштыра ала икән: аның белән күрешсәк, сөйләшеп сүзебез бетми, коедан суыбыз китми...* Н.Гамбәр. *Үзе белән аты арасында күпме рухи уртаклык, тәңгәллек бар икән ич аларның.* Р.Мөхәммәдиев

**ТӘҢКӘ** *и.* **1.** 1) Яссы түгәрәк металл акча. *Ул чүлмәктән унбиш көмеш тәңкә алган да, үгезен күл буенда калдырып, өенә йөгергән.* Әкият. *Кылыч борынлы, юка иренле дьякның кесәсенә алтын тәңкә дә шудырып карады, файдасы гына тимәде.* М.Әмирханов

2) *сөйл. к.* **сум** I. *Минем биш йөз тәңкә җитеп торырга да мөмкин аңа.* М.Хуҗин. *– Алдашкан кешеләрне яратмыйм, – дип, Хәләф тегенең учына биш тәңкә акча салды.* Х.Ибраһим

3) Кайбер умырткалы хайваннарның, балыкларның, еланнарның тәннәрен саклый торган катламны хасил иткән түгәрәк формадагы юка мөгез матдә. *Таҗиның әтисе балыкларны сөйри дә чыгара, сөйри дә чыгара. Ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны.* А.Алиш. *Кайбер скатларның тиресе шома, ләкин күбесендә акуланыкына охшаган тәңкә һәм чәнечкеләр үскән.* Т.Шакирова

4) Кайбер төр агачларның кәүсә кабыгын яки нарат, чыршы күркәләрен тәшкил иткән вак юка түгәрәк; кабырчык. *Җете кызыл көрән төстәге башак тәңкәсенең өске кырые аксыл элпәсыман.* Кызыклы ботаника. *Тышкы чәчәк тәңкәсе тиресыман, башакчык тәңкәсеннән катырак, эчке чәчәк тәңкәсен һәм бөртекчәне нык кочып үсә – һәрвакыт каурыйсыман озын кылчыклы.* Агулы үсемлекләр

5) Тимер акчага охшаган вак юка түгәрәк формасындагы берәр нәрсә. *Күрдеңме бабаңны, түше тулы тәңкә!* К.Тимбикова. *Улының җәелгән сул кулында көмеш тәре белән көмеш түгәрәк тәңкә ята иде.* З.Зәйнуллин

6) Сыеклык өстендә оешкан май һ.б.ш.ларның вак түгәрәк элпәсе яки кояш, ай һ.б.ш. утының кечерәк түгәрәк рәвешендәге чагылышы. *Әнә су өстендәге көмеш тәңкәләргә кара. Нинди матур тибрәнәләр.* Г.Әпсәләмов. *Сәгать икедә ашханәдә берәр савыт өшегән кәбестә шулпасы бирелә. Аның өстендә тәңкәләр йөзеп йөри.* М.Мәһдиев

7) Вак кар бөртеге. *Тунына кар тәңкәләре очып-очып куна.* Р.Вәлиева

8) Бизәнү әйбере буларак хатын-кыз толымына кушып үрелә торган, бауга яки тасмага таккан яссы металл түгәрәкләр, гадәттә, тимер акча; чулпы. --- *толымнарының очына тәңкә урынына алсу тасмалар чачаклаган кызкайны бик тә ошата, бик тә.* А.Хәлим

9) Түгәрәк формадагы вак, юка, яссы әйбер. *Алтын тәңкәләрен коя каен, Бәлки, шулай хәер бирәдер?* М.Сафин. *Ул әле таллыктагы күл өстенә тәңкәләрен җәеп яткан төнбоек өстендә пәйда була, әле гүя аккошлар арасында йөзеп йөри.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ. шигъ.* Вак, юка һәм яссы түгәрәк формадагы. *Тәңкә карлар шундый эре ява, әйтерсең күктән әкрен генә, тын гына ак чәчәкләр коела.* Г.Әпсәләмов

◊ **Тәңкә кебек шалтырап (ялт итеп)** *к.* **иске бер тиен кебек**. *Тәңкә*

*кебек шалтырап, тагын кайттым Көтү көтеп үскән җиремә.* Ә.Ерикәй. **Тәңкәнең икенче ягы** Эшнең, мәсьәләнең күренмәгән, билгеле булмаган икенче ягы; нәрсәнең дә булса бик үк әйбәт булмаган яки кимчелекле ягы. *«Таяк ике башлы», «Тәңкәнең икенче ягы да бар», ди халык.* Р.Вәлиева. *Хәер, артык саранлык, карунлык та – шул ук тәңкәнең икенче ягы: экономия хакында гына уйлап йөргән артык сакчыл, вакчыл адәмнәрнең яшәү рәвеше дә кызыгырлык түгел.* Шәһри Казан

**ТӘҢКӘ́КАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Канатлары тәңкәсыман ялтырап тора торган тулы әверелешле бөҗәкләр отряды; күбәләкләр; *русчасы:* **чешуекрылые**. *Ә хәзер, доктор Уотсон, өске катка меник, мин сезгә тәңкәканатлылар коллекциясен күрсәтермен.* Р.Вәлиев

**ТӘҢКӘЛ** *и. диал.* Артсыз урындык; табуретка. *Тәңкәлгә утырдым*

**ТӘҢКӘЛӘНҮ** *ф.* Тәңкәне хәтерләтү; тәңкә рәвешен алу. *Әйтерсең урман өстенә бриллиант тузаны яуган: бөтен җир – агач ботаклары, ачык урыннар – бар да уттай яна; мамыктай күперенеп, тәңкәләнеп каткан кар өстеннән кояш нурлары кире чәчриләр, һич туры карап булырлык түгел.* Ә.Еники. *Алтынчәч Линар белән янәшә йөзеп китте, кояш нурында тәңкәләнеп ялтыраган Идел киңлеген күрде, тәне суның салкынча назын тойды.* М.Маликова

**Тәңкәләнеп тору** Гел тәңкәләнү; хәзер тәңкәләнү. *Елга өсте тәңкәләнеп тора*

**ТӘҢКӘЛӘП** *рәв.* 1) Билгеле тәңкә чамасында; үзеннән алда килгән сан белдергән тәңкә күләмендә. *Әмма, кияү, ул бурычны өч тәңкәләп түләп этләнмә инде, яме.* З.Зәйнуллин

2) Тәңкә-тәңкәгә аерып, берәр тәңкә итеп. *Бер тәңкәләп хатыныннан акча теләнгән чакларын онытткан.* С.Зыялы

**ТӘҢКӘЛӘТҮ** *ф.* Тәңкәләр белән бизәтү, тәңкәләр куйдыру. *Яшь Мәрхәбә өстенә, башкорт хатыннарыныкы кебек билен, күкрәген тәңкәләтеп, бишмәт тектерде.* Г.Ибраһимов

**ТӘҢКӘЛЕ** *с.* 1) Тәңкә белән капланган. *Класска кереп утыргач та күз алдыннан тәңкәле балыклар китмәде.* И.Диндаров. *Тәңкәле балыктай вак дулкыннар сикерештe.* Ф.Җамалетдинова

2) *иск.* Бай, барлыклы, зиннәтле бизәнү әйберләре булган. *Алмачуар тайларда, Тәңкәле кыз байларда, Бу ай үтеп, киләсе айда Без булырбыз кайларда.* Җыр

**ТӘҢКӘЛЕ́ БӨҖӘК** *и. зоол. к.* **тәңкәтән**

**ТӘҢКӘЛЕЛӘР** *и. күпл. зоол. к.* **тәңкәтирелеләр**. *Хәзерге сөйрәлүчеләрнең отрядлары: тәңкәлеләр (еланнар, кәлтәләр һәм хамелеоннар), крокодиллар (крокодиллар һәм аллигаторлар), ташбакалар һәм томшыкбашлылар (безнең көнгә кадәр сакланган бердәнбер төре – гаттерия).* Биология

**ТӘҢКӘЛЕ́ ТИМРӘҮ** *и. мед.* Тәнгә ак тәңкәләр белән капланган тимгелләр чыгудан гыйбарәт йогышсыз, дәвамлы тире авыруы. *Псориаз (тәңкәле тимрәү) чире кавыкланып торган ак тәңкәчекләрдән гыйбарәт.* Сөембикә. *Экзема, тәңкәле тимрәү, хейлит (ирен ялкынсынуы) кебек тире авырулары вакытында көнгә 2 мл сырганак мае эчү яки мазь рәвешендә тирегә ягу да бик файдалы.* Мәйдан

**ТӘҢКӘ́ ПЕЧӘН** *и. бот.* Сыражчалар семьялыгыннан башаксыман чук чәчәк төркеменә урнашкан чәчәкле, өлгергәннән соң селкенгән вакытта шалтырый торган диск формасындагы орлыклы берьеллык ярымпаразит үсемлек; *русчасы:* **погремок**

**ТӘҢКӘ САЛЫШ** *и. этн. к.* **йөзек салыш**. --- *аулак өйнең өйалды ишегe төбенә хәтле ачык, өй эчендә инде гармун тарталар, егетләр-кызлар, тышта әле генә узган котчыккыч бәрелешләрдән бөтенләй бихәбәр булып, тәңкә салыш уйныйлар.* М.Мәһдиев

**ТӘҢКӘТӘН** *и. зоол.* Төккойрыклылар семьялыгыннан бик кечкенә, нәзек озынча гәүдәле, көмешсу тәңкәләр белән капланган, өйләрдә яки азык-төлек складларында була торган бөҗәк; *русчасы:* **чешуйница**. *Беренчел канатсызларга камподея, койрыгаяк, шикәр тәңкәтәне һ.б. кебек иң гади төзелешле бөҗәкләр керә.* Биология

**ТӘҢКӘ́-ТӘҢКӘ** *с.* Тәңкәләр сыман, тәңкәләрне хәтерләткән, тәңкәләргә охшаган. *Алар, әллә юри инде, үзләре артыннан тәңкә-тәңкә түгәрәкләр калдырып, малайларның күзен кызыктыралар.* Ф.Зыятдинов. *Су өстендә тәңкә-тәңкә ак күбекләр йөзә.* Д.Бүләков

**ТӘҢКӘТИРЕЛЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Өске тиреләре мөгез тәңкә белән капланган сөйрәлүчеләрне (кәлтәләр, еланнар, хамелеоннар) берләштерә торган отряд; *русчасы:* **чешуйчатые**. *Башка рептилияләрнең икешәр пар очлыклары һәм һәр очлыкта тырнаклы бишәр бармагы бар. Алар дүрт отрядка бүленә: тәңкәтирелеләр, ташбакалар, крокодиллар һәм томшыкбашлылар.* Т.Шакирова

**ТӘҢКӘЧУАР** *и.* Тәңкә-тәңкә булып торган аксыл, каралҗым таплары булган җирән яки күк төстәге (ат тур.). *Татар телендә утыздан артык ат төсмере аерымлана: ак, акбүз, алмачуар, болан, бурлы (бурыл), бүз, бүртә, калтар, кара, кир, коба (куа), кола, коңгыр, кыярчуар, көрән, күк, күк ала, күкҗирән, сары, тимеркүк, таргыл, туры, тәңкәчуар, чагыр, чал, чалка, чуар, чел, чөлкәр, җара, җирән һ.б.* Р.Әхмәтьянов

**ТӘҢКӘ́ЯФРАК** *и. бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан яфраклары бармаксыман аерчалы, яшькелт төстәге вак чәчәкле үлән үсемлек; төкле чәчәк; *русчасы:* **манжетка**. *Боларның кайсысы ерткыч үсемлек? а) уңъяфрак – стрелолист; ә) чыклы үлән – росянка; б) тәңкәяфрак – манжетка.* Р.Кәбирова. *Манжетка – тәңкәяфрак – чыннан да, файдалы матдәләргә ифрат бай үсемлек икән.* Ватаным Татарстан

**ТӘҢРЕ** *и.* 1) Төрки, монгол, тунгус-маньчжур халыклары мәҗүсилегендә күкнең һәм бөтен дөньяның хуҗасы. *Тәңре аны: «Улым, син монголларның императоры булырсың! Сине алда чиксез зур дан-шөһрәт көтә!» – дип яраткач, ничек үтертсен инде?* А.Хәсәнов

2) Гомумән Аллаһ, Ходай. *Тик шулай да күктән Тәңре күреп тора, синең кебек мин эчкерле, үчлекле түгел, Ямгырчы би!* Н.Фәттах. *Монголиянең вак комын ашавы, Казан пычрагын җыюы, элеккеге хатыннарының аңламавы өчен җибәрде аңа Тәңре Зөлфияне.* Т.Галиуллин

◊ **Тәңре йорты** Мәчет, гыйбадәтханә. *Алар өчәүләшеп әкрен генә Тәңре йортына юл тотты.* Ш.Маннур. **Тәңренең биргәненә шөкер** *к.* **Аллага шөкер**. *Бай, гадәт буенча, Тәңренең биргәненә шөкер, дигән мәгънә белән ит өстенә карап бит сыйпады да табакны җылкычы атага табарак этәрде.* Г.Ибраһимов. *Тәңренең биргәненә шөкер, мине алыштырыр оланнарым бар, дип хыялланып ятты чирү башы.* Р.Сәгъди. **Тәңренең бирмеш көне** Һәр көнне, көн саен. *Әгәр хәзерге заманда үтә динле, шул ук вакытта табигать белеме белән дә бераз таныш бер агайга, Кояш Тәңренең бирмеш көне Җир читендәге сасы суга төшеп баййый икән, дисәк, сезнеңчә ничек, агай ышаныр идеме?..* Г.Гобәй. --- *Иван Кузьмич, бик гадәти нәрсә турында гәп саткандай, сөйләнүен белде: – Ә бит адәм баласына Тәңренең бирмеш һәр көнендә теш арасына кыстырырга икмәк, җылыда йоклыйм дисә – утын, дөньяга чыгыйм дисә – кием-салым кирәк.* М.Хәсәнов. **Тәңренең язмыш көне** *к.* **Тәңренең бирмеш көне**. *Кичәкөндез ошбу җирдә, Тәңренең язмыш көне, Капчыгын тоткан, сорана җәй вә көз, яз, кыш көне.* Г.Тукай. **Тәңре үзе генә белсен** *к.* **Алла белсен**. *Тәңре үзе генә белсен, ул караңгы бүлмәнең тын, куе караңгылыгы эчендә озын төннәрдә нинди серләр, нинди яшеренлекләр саклanaдыр.* Г.Ибраһимов. **Тәңре үзе сакласын** *к.* **Алла сакласын**. *Ир балалар арасыннан Талгун кебек мөртәтләр үсеп чыкса... Тәңре үзе сакласын!* Р.Сәгъди. **Тәңре хакы өчен** *к.* **Алла хакы өчен**. *Зинһар, Тәңре хакы өчен җәяүләп!* Р.Батулла. *– Бөек Тәңре хакы өчен әйт, исемең ничек? – дип, түбәнчелек белән сорады.* Ф.Яхин. **Тәңре хакы өчен дә** Бөтенләй, һич тә, бик аз гына да. *Искиткеч бит, күк йөзендә Тәңре хакы өчен дә бер болыт юк.* И.Нуруллин. **Тәңре ярдәм бирсен** *к.* **Тәңре ярдәм итсен**. *Тәңре ярдәм бирсен юлчыларга!* Г.Сөнгати. **Тәңре ярдәм итсен** Кемгә дә булса эше, киләчәк тормышы уңышлы булуын теләү сүзе; Алла ярдәм бирсен. *Тәңре ярдәм итсен инде, бернишләп тә булмый.* Р.Вәлиев

**ТӘП-** Кайбер сыйфат яки рәвешләрнең артыклык дәрәҗәсен ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Өстән, биектән озын-озын яугирләр, олы гәүдәле бәкләр тәп-тәбәнәк булып күренә...* Р.Батулла. *Сүрән генә ут яктысында Ләйсирә белән икәү генә тәп-тәмле чәйне иплән кенә эчеп утырабыз.* М.Вәлиев

**ТӘП** I *и.* 1) *диал.* Корылма, каралты сала башлар алдыннан аның нигезен билгеләгән беренче ориентир нокта: казык, таш өстенә куелган таш һ.б.ш.лар

2) *мат. иск.* Озынлык, биеклекне үлчәгәндә үлчәү башы итеп билгеләнгән нокта

3) Чиртеш уенында берсе өстенә берсе төшкән шакмакларның сыңары. *Тәпкә чиртү*

**ТӘП** II *и. фар.* Шөлдерле бәрмә уен коралы; дөңгер, дәф. *Тәпкә типмә – балаң елак булыр.* Мәкаль

**ТӘПӘВЕЧ** *и.* 1) *к.* **тәпәч**

2) *сөйл.* Бер сүзне кат-кат сөйләүче кеше

**ТӘПӘК** *и. иск.* Керне бәрә-бәрә юу, кипкәч, керне йомшарту өчен, аркылыга кабыргалар уеп ясалган яссы агач әсбап; бәләк. *Элек керне тәпәк белән юганнар, кипкәч тәпәк белән йомшартканнар*

**ТӘПӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) *иск.* Тәпәк белән эшкәртү

2) *диал.* Кыйнау, бер-беренә сугу. *«Камай» белән «Сәкәш»ләр Берен берсе тәпәкләр.* Такмак

**ТӘПӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тәпәләү**. --- *үз даирәләрендәгеләрнең җиңел кулдан тәпәләнгән икенчел әсәрләрен дөньяга чыгару белән артыграк мавыгу аркасында, асыл максат күптән онытылганмы?* Р.Зарипов. *Үземне тәпәләнгән, мәсхәрәләнгән бер йолкыш итеп күз алдына китердем мин ул ишегалдында.* Безнең гәҗит

2) *диал.* Баш аркылы атылу, мәтәлчек ату, мәтәлү

**Тәпәләнеп китү** Кинәт кенә тәпәләнү. *Вәлиев уң кулы белән элек Шамилнең җилкәсенә каерылып сукты. Шамил тәпәләнеп китте.* А.Таһиров

**Тәпәләнеп тору** Әледән-әле, еш яки даими тәпәләнү. *Икенчел сафлыктагы романнар тәпәләнеп тору могтәбәребезне дә ифрат борчый икән...* Р.Зарипов

**ТӘПӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Суккалап тору; тәпәү, тәпәкләү. *Нигә тик торганнан җирне тәпәли соң бу Хода бәндәсе?* Г.Гыйльманов

2) *сөйл.* Кыйнау, тукмау, күп тапкыр сугу. *Митя көндезгәчә үлеп йоклый, --- торгач, ике сәгать гимнастика ясый: гер күтәрә, коридор буйлап чаба, --- бүлмә почмагына эленгән бокс грушасын төя, тәпәли, соңыннан бозлы су белән юына.* А.Гыйләҗев. *Үзе ничә еллар буе тәпәләп эшләткән егетләрнең кулы астында калса, ни буласын яхшы аңлый ул.* Ф.Садриев

3) *күч.* Кемне дә булса бик каты тәнкыйть итү, фаш итү. *[Г.Камал] Үзенең сатирик талантын киң рәвештә җәелдереп, реакцион көчләрне тәпәләргә керешә.* М.Гали

4) *күч.* Ашык-пошык, аннан-моннан гына эшләп кую. *Ашык-пошык тәпәләгән җилкапкасы каерылып төшкән.* Ш.Маннур

**Тәпәләп алу** Тиз-тиз хәрәкәтләр ясап, бераз тәпәләү. *Үземнән ике яшькә генә олы Азат еш кына мине тәпәләп ала.* И.Гыйләҗев. *Мәнә бу җен баласын тәпәләп ал әле!* Х.Ибраһим

**Тәпәләп ату** *к.* **тәпәләп ташлау**. *Әллә соң «даһи» нәрсә тәпәләп атгым микән, дип пошаманга төшәрсең, билләһи!* Р.Зарипов

**Тәпәләп бетерү** Беткәнче, ахырга хәтле тәпәләү; бик нык тәпәләү. *Сабах намазымны укып, тәпәлисе печәнне тәпәләп бетердем.* А.Хәлим

**Тәпәләп ташлау** Тиз арада тәпәләү. *Шул чакыру авазы җитә калды, егетләр шәһәрнекеләрне тәпәләп ташладылар.* Д.Каюмова. *Урамда очратсалар, яшьләр тәпәләп ташларга да күп сорамаслар.* К.Кара

**Тәпәләп тору** Еш, әледән-әле тәпәләү; һәрвакыт тәпәләү. *Мәктәптә дә көчлерәк малайлар әледән-әле тәпәләп торганнар үзен, көн саен чыгарган такмаклары өчен.* Ф.Баттал. *Бу дөрес хәбәр түгел, андыйларны чир ала диmeни, аюларны тәпәләп торган әзмәвер ич ул Иоанн!* М.Әмирханов

**Тәпәли башлау** Тәпәләргә тотыну. *Госманның кистән алуын күрүгә, кол урыныннан торды да әмиргә ташланды һәм, аның кистәнен тартып алып, үзен тәпәли башлады.* Әкият. – *Безнекеләр өелешеп килделәр дә моның иптәшләрен тәпәли башладылар, – диде Көтек дигәне.* Н.Харисова

**ТӘПӘЛӘШҮ** *ф. сөйл.* Сугышу, кыйнашу. – *Бүсеренә тибегез, Тимерҗан, бүсеренә! – дип кычкырды Шәми, тәпәләшкән малайларны котырткан кебек.* Р.Батулла. *Теләсә кая кысылып йөрүчене дә, тәпәләшергә яратучыны да кичке уенда өнәп бетермиләр шул.* Х.Гайнетдинов

**Тәпәләшә башлау** Тәпәләшергә керешү. *Син хәрәмләштең, син, дип, еш кына тәпәләшә башлыйлар.* Сабантуй

**Тәпәләшеп алу** Тиз арада, бераз тәпәләшү; тәпәләшергә дә өлгерү. *Дусларча уйнап, шаярып, ара-тирә тәпәләшеп тә алып, дүрт ел яшәдек Гаптерәхимнәр өендә.* Р.Ишморат. *Көннәрнең берендә Искәндәр яшьтәше белән тәпәләшеп алды.* М.Кәбиров

**Тәпәләшеп йөрү** Төрле урыннарда, бик еш тәпәләшү. *Мәскәүнең Манеж мәйданында һәм Петербургта меңләгән яшьләрнең, йодрыкларын чөеп, хакимияттән ризасызлык белдереп, милиционерлар белән тәпәләшеп йөрүе гади халыкны гына түгел, ил җитәкчеләрен дә сискәндереп җибәрде.* Ватаным Татарстан

**Тәпәләшеп китү** Кинәттән генә тәпәләшергә тотыну

**Тәпәләшеп тору** Һәрвакыт, гел тәпәләшү; әле, хәзерге вакытта тәпәләшү; күз алдында тәпәләшү

**Тәпәләшеп яту** *к.* **тәпәләшеп тору**. *[Идрис белән Таһир] Тәпәләшеп ятканда, алар янына Таһирның әнисе – зур гәүдәле, юан аяклы, һәрчак усал калын тавышлы Рәисә апа килеп басты.* Ә.Сәгъди. *Колагымнан наушникларны алып, ни булды икән дип карасам, өч егет, үгез кебек акыра-акыра, автобус уртасында тәпәләшеп яталар.* Татарстан яшьләре

**ТӘПӘН** *и.* 1) Агачның үзәген чокып һәм төпләп ясалган кечерәк кисмәк. *Алпавыт: «Әнә тегендә су белән тулы бер тәпән тора. Һичбер чит әләтсез шул суның төгәл яртысын түксәң, [бөладән] коткарырмын», – дигән.* Әкият. *Иван бездән йөз баш ат, сигез ияр, биш тәпән бал, бер арба җофар, кондыз гына таләп итәр дип уйлыйсызмы?* Р.Батулла

2) Гомумән кечерәк агач савыт. *[Җиләклектән] Инде тәпәннәрне тутырмый кайтырга ни!* М.Фәйзи

3) *күч.* Юан, тәбәнәк кеше турында. *Тәпән Шакирга бу кушаматның ни сәбәптән ябышканын әйтеп тә торасы юктыр, чөнки тәпән дә тәпән, гәүдәсенә карасаң, бу да тәпән: Ходай юанлыкны мул бирсә дә, буй бирмәгән монысына.* Ф.Баттал

◊ **Тәпән башы** *этн.* Кымыз тәпәне янында утырып, кымыз салып өләшеп торучы кеше. *Тәпән башы булып алырга өлгергән Федот --- савыт-сабаларны читкә этәрә-этәрә, аракыны бадьяга койды.* Л.Зөлкарнәй

**ТӘПӘНЛӘП** *рәв.* 1) Бер тәпән чамасы

2) Тәпәнне тутырып, тәпәне белән; тәпән-тәпән итеп. *Атланмаем каплamaлап, сары маем тәпәнләп, туңмайларым табаклап ята.* Т.Гыйззәт

**ТӘПӘНЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Буе җитмәүдән аяк бармаклары очларына басып күтәрелү. *Тәпәнләп тә киштәгә буй җитмәде*

2) Вак-вак адымнар белән карыша-карыша тартышып атлау. *Кармак таягын ике куллап чытырдатып тоткан, ә үзе, --- зеңләп тартылган җепкә тагылып, арыш капчыгы шикелле аска тәпәнли...* Ф.Баттал

**ТӘПӘ́Н-ТӘПӘН** *с.* **1.** Бик күп тәпәннәргә тутырылган, күп тәпәннәрдән торган. *Киштәләрдәге елкылдавык тиреләр, өем-өем күннәр, тәпән-тәпән баллар әз генә дә аның күз алдыннан китеп тормады.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәпәнләп; тәпәннәр белән

**ТӘПӘРЛӘНҮ** *ф. диал.* Йомарлану, бөгәрләнү, бөрешү. *Андый сөлге тиз тәпәрләнә, таушала, кыяфәтен һәм сыйфатын югалта.* Безнең гәҗит

**Тәпәрләнеп бетү** Тәмам, бик нык тәпәрләнү. *[Нәзирнең] Сакал-мыегы җиткән, күзләре эчкә баткан, киемнәре тәпәрләнеп беткән.* Х.Мөдәррисова

**Тәпәрләнеп яту** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында тәпәрләнгән хәлдә булу. *Анда берничә кара тышлы мендәр ауный, шулар янында кыйммәтле атластан, бөтен түше алтынга манылган тәңкәләр белән тулы хатыннар киеме тәпәрләнеп ята.* Г.Ибраһимов

**ТӘПӘРЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Бөгәрләү, йомарлау, бөрештерү

2) *күч.* Каты кыйнау

**Тәпәрләп бетерү** Тәмам, бик нык тәпәрләү. *Өс-башыңны тәпәрләп бетермә*

**ТӘПӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Тәпкеләү (*1 мәгъ.*), тапау

2) *к.* **тәпәләү** (*1, 2 мәгъ.*). *Ирен туйганчы тәпәп, аннары типкәләп ишектән чыгарып җибәргәч, берочтан җиңгигә дә очып кунмакчы иде, җиңги якын да китермәде.* В.Нуруллин

**Тәпәп алу** Бераз, аз гына тәпәү. *Нәрсә булды? Анысын Солтан белә. Печтик кенә тәпәп алдылар.* Һ.Такташ

**ТӘПӘЧ** *и.* **1.** 1) Кыска һәм юан таяк. *Кулларына бер башы йомры, икенче башы үткен итеп юнылган тәпәчләр тоттылар.* Г.Гыйльманов. *Халык, Атакай дәрвиш белән Кошчакны уртага алып, --- гөрзи, тәпәч, янпычакларын баш очына алгач, мирзаларның кикриге шиңде.* Р.Батулла

2) Кузна, буралы һ.б.ш. уеннарда: тупырчыкларны, кузналарны сызыктан яки оядан бәреп чыгару, тәгәрәтеп җибәрү өчен ыргыта торган кыска таяк; аткы. *Уен кызып кына барганда, мин, оядагы пушканы бер бәрүдә сугып чыгарыйм әле дип, тәпәчемне бар көчемә ыргыткан идем, бер шакмак чәчрәп китте.* Р.Төхфәтуллин

3) Башактагы орлыкларны кою өчен, озын таякка каеш белән беркетеп куелган, көлтә җәеменә бәрә торган кыска таяк өлеше; чабагач таягы. *Ындыр табагында төннәр буе Тәпәч белән ашлык сугулар.* Р.Сәйфетдинов

4) *күч. гади с., тирг.* Аңгыра, миңгерәү, булдыксыз кеше турында. *Тәпәч, бу бит Дәрвиш түгел, Кырлай авылы тимерчесе Абдулла малае Батырҗан бит.* А.Гадел

**2.** *с. мәгъ.* 1) Юан агач таяктан ясалган. *Гражданнар сугышында бер аягын югалтып кайткан Мәгънәви карт стена буендагы сандыкка кунакларга уйласа да, бөгелми торган тәпәч аяк бер якка да сыймады.* Х.Мөдәррисова

2) *күч.* Зур, иләмсез, тупас. *Штанга күтәрү буенча иң симез абзыйлар арасында чандыр гәүдәле Маратны күреп, ярышны алып баручы кызгылт тәпәч борынлы җирән судья башын чайкап елмаеп куйды.* Д.Гыйсметдин

**ТӘПӘЧЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тәпәчләү**

2) *күч.* Тәпәч кебек бөгелми, сыгылмый торганга әйләнү, катып китү. *Йөри-йөри, аягым тәпәчләнде*

**Тәпәчләнеп бетү** Тәмам, бик нык тәпәчләнү

**ТӘПӘЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәпәч яки шуңа охшаш нәрсә белән суккалау

2) *сөйл.* Кыйнау

**Тәпәчләп алу** Бераз, аз гына тәпәчләү

**Тәпәчләп ату** Бик нык тәпәчләү

**Тәпәчләп бетерү** Ахырга кадәр тәпәчләү, беткәнче тәпәчләү. *Көлтә җәемен тәпәчләп бетерү*

**Тәпәчләп ташлау** *к.* **тәпәчләп ату**

**Тәпәчләп тору** Әле, хәзер, күз алдында тәпәчләү; һәрвакыт, гел тәпәчләү

**Тәпәчләп чыгу** Барысын да ахырга кадәр тәпәчләү, беткәнче тәпәчләү. *[Хәлим] Җәемгә көлтә тезешә, бер кат тәпәчләп чыккач, көлтәләрне әйләндерергә булыша.* И.Гази

**Тәпәчли башлау** Тәпәчләргә тотыну

**Тәпәчли төшү** Тагын да ныграк тәпәчләү

**ТӘПӘШ** *с. диал.* 1) Тәбәнәк. *Тәпәш кенә бер йорт, һәм биш йолдыз балкый аның кәрниз тышында...* Ә.Дусайлы

2) Кыска буйлы, базык. *Белорус кызының моңа кадәр татарларны күргәне юк иде. Нигәдер кысык күзле, тәпәш, кәкре аяклы, ат өстеннән төшмәс кырыс табигать халкы итеп күз алдына китерә иде ул аларны.* З.Мурсиев

**ТӘПЕЛДӘ́Ү** *ф. сөйл.* Күп йөрү, йөгерү. *Аягың тәпелдәп торса, авызың чәпелдәп торыр.* Мәкаль

**ТӘПИ** *и.* 1) Кош-корт һәм хайван аягы. *Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр бөрешеп утыра.* Г.Бәширов. *Бер читтә, башын алгы тәпиләренә салып, усал эт йокымсырап ята.* И.Диндаров

2) Балалар аягы. *Ул режим мәктәп балаларына гына түгел, әнә теге зур киез итекләрнең төбенә тәпиен җиткерә алмыйча --- йөрүче ташбаш малайга да кагыла.* М.Мәһдиев. *Каршысына, бәләкәй тәпиләре белән тып-тып басып, Гарсия йөгереп килде.* К.Кара

3) *сөйл.* Аякның табан өлеше. *Кояшлы язгы көн белән хозурланып, Уфа урамнары буйлап озак йөрде алар, аяк астында берөзлексез юеш кар һәм язгы су чыпырдады, чолгаулары юешләнеп, тәпиләре чырараганны да тоймадылар.* Р.Мөхәммәдиев

4) *сөйл.* Нинди дә булса җиһаз аякларының кеше яки хайван аягы табанына охшатып эшләнгән, җиргә, идәнгә бастырып куя торган терәге; аяк. *Эскәмия тәпиендә мәш килгән кырмыскалары да, колак артында быжылдап торган кигәвеннәре дә парлы, менә мин генә ялгыз, мин генә бәхетсез, дип уйлады ул [Әхмәтҗан].* Р.Рахман

◊ **Тәпи басу** 1) Яшь бала егылмыйча аягында басып тора башлау. *Әти, әйдә, минем беренче тәпи баскан көннәремне хәтерләп, рәсем яса!* Н.Гыйматдинова; 2) Тормыш рәтләнү, хуҗалык җайга салыну. *Яңасала да тәпи бассын, атларга да дәрт керсен!* Г.Бәширов. **Тәпи йөрү** Чит ярдәмнән башка, яшь бала үз аягына басып, йөреп китү. *Тәпи йөри башлагач, әбисенең туктаусыз кисәтеп торуына карамастан, өйалдына чыгып йөри башлый тиктормас.* К.Җәмит. **Тәпи китү** *к.* **тәпи йөрү**. *Дөньясы түгәрәкләнгән Фәридә тәпи киткән кызын кайнанасы кулына тапшырып эшкә чыкты.* К.Кара. **Тәпи сузу** Үлү. *Менә шулай тудыйм-судыйм ике тапкыр килсәң, ул арада теге түти тәпиен сузып куйса, менә сиңа мә – шәһәр уртасында ике бүлмәле фатир.* М.Мәһдиев. **Тәпи тоту** Тустыру, аяк тоту. *Минем үземнең, әлхәм шөкер, --- кемгәдер селәү дә саплаганым юк, сабыйларымнан башкаларны тәпи дә тотканым юк.* Ф.Баттал

**ТӘПИЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Җәяү бару, җәяүләп, атлап бару. *Ике ара шактый ерак булса да, яшь ярымлык Ания әнисе белән янәшә бик кәефләнеп терек-терек тәпиләде.* Г.Галиева. *Алар, аллыартлы, яшел чирәм өстендәге күлләвекләрне лычтыр-лычтыр китереп, өй ягына тәпиләделәр.* М.Әмирханов

2) Йөри башлау, тәпи китү. *Әйтерсең лә башка илләр шушы төбәктән әниләренең итәгеннән төшкәч тәпиләп киткән сабыйлар шикелле бар җиһанга таралган, чәчелгән кебегрәк килеп чыга.* В.Имамов

**Тәпиләп китү** Тәпиләргә керешү, тәпили башлау

**Тәпили башлау** *к.* **тәпиләп китү**. *Ерактан гына якын төсле ул, тәпили башласаң, тагын биш чакрым җыясың.* Н.Гыйматдинова. --- *вакыт узып, аякка баскач, мин ашханәгә үзем тәпили башладым.* Д.Гыйсметдин

**ТӘПИ́-ТӘПИ** *рәв.* 1) Тәпигә басып, тәпи йөреп. *Сез әле бәләкәй чакта ук, тәпи-тәпи атлап киткәнче үк, дүрт аяклап мүкәләп йөреп, дөньяны, тормышны өйрәндегез.* Т.Миңнуллин

2) Җәяү, җәяүләп. *Станцага малаен муенына атландырып, чемоданнарын кулына тотып, тәпи-тәпи китеп барган.* Т.Галиуллин. *Үз гомерендә беренче мәртәбә хан кызы, тәпи-тәпи үз аяклары белән, тегүче Хәсән улы Галәветдингә җәяүләп кияүгә барсын әле!* А.Гадел

**ТӘПИЧӘ** *и. бот.* Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан бармаксыман яки өч аеры яфраклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **лапчатка**. *Татарстанда үскән үсемлекләр арасыннан танин чималы булып, бүкчәләләр семьялыгына кергән гади имәннең ялтыравыклы яшь кайрысы, --- розачәчәкләләрдән дарулы кызылбаш тамырчалары, шул ук семьялыкка караган төз тәпичә тамырчалары --- саналалар.* Ф.Закиров. --- *тәпичә тамырларын --- үсемлек маена кушып, бер сәгать буе су мунчасында җылыталар, үкчәнең ярылган урыннарына сөртеп, бинт белән бәйлиләр һәм төнгелеккә калдыралар.* Мәдәни җомга

**ТӘПКЕ** *и. рус* 1) Үсемлекләрне, яшелчәне чапкалап ваклау, тураклау өчен кулланыла торган, пычагы ярымай

рәвешендәге саплы корал; чапкы. *Кузы чикләвегенең төшен тәпке белән вак-лыйлар, нәкъ чикләвек төше кадәр шикәр комы кушалар һәм җиде тигез өлешкә бүләләр.* Татар халык ашлары

2) *диал.* Китмән. *Аның --- берүзенең гектары белән чөгендер басуын тәпке белән эшкәртеп чыгуына --- һәммә кешеләр таң калуда вә гаҗәпләнүдә иделәр.* Ф.Яхин

**ТӘПКЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Үсемлекне, яшелчәне тәпке белән чапкалап тураү

2) *диал.* Китмәнләү. *Кура җиләгенең туфрагын, гадәттә, казымыйлар, аны бары тик җиңелчә генә тәпкелиләр.* Ватаным Татарстан

**Тәпкеләп алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында тәпкеләү

**Тәпкеләп бетерү** Ахырына кадәр тәпкеләү. *Бәрәңге бакчасын тәпкеләп бетергәч, әни --- югары очта яшәүче абыйларга менеп киткән.* Татарстан яшьләре

**Тәпкеләп тору** Әледән-әле, еш тәпкеләү

**Тәпкеләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тәпкеләү

**Тәпкели башлау** Тәпкеләргә керешү

**ТӘ́П-ЛӘП** *иярт. рус* Аннан-моннан, тырышмыйча гына эшләү рәвешен белдерә. *Башта тәп-ләп кенә эшләп киткәннәр иде.* Ф.Яруллин

**ТӘПСЕНЛӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **тәпсерләү**

**ТӘПСЕРЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Җентекләп, бөтен нечкәлекләренә дә игътибар биреп сөйләү, аңлату яки сорашу

2) Нечкәләп дикъкать итү

3) *диал.* Тәнкәрләү, талымлау, сайлану. *Алай дисәң, аның корсагы бер дә тәгамь тәпсерләми иде, көпчәк әзендәге җылымса, кортлы су эчкәннәре дә күп булды.* Р.Батулла. *Солдат кеше әйбер тәпсерләп тормый, ни бирсәләр, шуны ашый инде ул.* Р.Кәрами

**Тәпсерләп тору** Әле, хәзерге вакытта тәпсерләү. *Ач чакта тәпсерләп торып булмый инде.* Р.Батулла

**ТӘ́П-ТӘП** *иярт.* **1.** Вак-вак атлап, йомшак басып, яшь бала йөргәндә чыккан тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Нинди карт ди? Яшь бала кук тәп-тәп атлый әле дә ул.* Н.Исәнбәт

**ТӘП-ТӘ́П ИТҮ** *ф.* 1) Шундый тавышлар чыгару

2) *ирк.* Тәпи йөрү. *Менә Алмаз үскән инде, тәп-тәп итә хәзер ул.* Ялкын

**ТӘРАВИХ** *и. гар. дини* 1) Рамазан аенда ястү намазыннан соң укыла торган намаз. *Көнгә биш вакыт, рамазан айларында тәравих намазы да өстәлгәч, алты намаз була ич әле ул.* Г.Галиева. *Мәчеткә этисе Мирсәет абзый белән бергәләп йөриләр, ураза вакытында тәравих намазларын да калдырмыйлар.* Т.Нәҗмиев

2) Тәравих намазының һәр ике яки дүрт рәкәгатеннән соң тавыш белән көйләп әйтелә торган тәсбих, зикерләр. *Ул ураза аенда тәравих тыңларга йөрүче балалар арасында зур кеше --- исәпләнә.* Г.Толымбай

◊ **Тәравих әйтү** Тәравих намазының һәр ике яки дүрт рәкәгатеннән соң, көйләп, билгеле зикерләр уку. **Тәравих чәе** Ирләре мәчеткә тәравихка киткәч, хатыннарның аулакта эчә торган чәй мәҗлесе; гомумән шул вакытта эчелә торган чәй. *Бәдрикамал абыстай Бәдриҗамал абыстайны тәравих чәенә дәшәргә уйлады.* Г.Рәхим

**ТӘРАВИХЧЫ** *и. дини* 1) Тәравих намазына йөрүче кеше

2) Тәравих намазының һәр ике яки дүрт рәкәгатеннән соң көр тавыш белән көйләп зикер әйтүче махсус кеше

**ТӘРӘЗӘ** *и. фар.* 1) Өй, вагон һ.б.ш. корылмаларның эченә якты төшсен һәм һава йөрсен өчен, диварларына уелган ачыклык һәм шул ачыклыкка куелган пыялалы рам. *Шулай да тәрәзә аша төшкән ай яктысы сукыр шәмнекеннән бер дә ким түгел.* С.Поварисов. *Бер катлы җәйге тәрәзә токасына кагылу белән, ике якка ачылып китте.* А.Тимергалин

2) Күзәтү, сөйләшү һ.б.ш. эшләр өчен, диварга уелган, диварда калдырылган тишек. *--- вахтёр кыз басып торган тәрәзә тишегә турысына килеп җиткәч, --- пропускысын сузганда, кесәдә әлеге сәгать шылтырады.* Н.Хәсәнов. *Габделнур регистратура тәрәзәсенә башын тыгып ризасызлык белдерде.* Р.Кәрами

3) *хәрби* Яшеренеп ату өчен, хәрби нығытмаларның диварына ясалган махсус уем, тишек; амбразура. *Күп гасырлар элек шәһәрне саклаучылар бу тәрәзәләр аша ук атканнар, шулай итеп дошманнан сакланганнар.* Әкият. *--- качып ук атар өчен [ясалган] кала диварларындагы тишек, тәрәзә.* Р.Батулла

4) *күч.* Экран; монитор. *Һәй, бик керәсем килә дә, шул тилевизыр дигәннең тәрәзәсеннән диктор исемле хатын гел миңа карап сөйли.* Т.Миңнуллин

5) *күч.* Ике дәрес яки смена арасында калган буш сәгать. *Минем буш дәресем – тәрәзәм бар иде. Дәфтәр караштырып утыра идем.* Э.Касыймов // Гомумән эш арасында нинди дә булса сәбәп аркасында бушка үткән вакыт. *Бу хәл соңгы вакытта әзер буровойлар булмау аркасында туган тәрәзәләр санын шактый киметте.* Ә.Маликов

6) *күч. иск.* Иске мәдрәсәләрдә чаршау белән бүлмә сыман итеп бүленеп куелган бер кешелек урын. *[Ул] Угылын алып килеп, үзенең тәрәзәсенә урнаштырганнан соң, мәдрәсәдән чыгып китте.* Шура

7) *күч. сөйл.* Тишек, ертык. *Аңардан качып йөри-йөри, чалбар төбе тәрәзә булды.* Һ.Такташ

◊ **Тәрәзә ачу** Чит илләр белән сәяси, мәдәни, сәүдә һ.б. өлкәләрдә аралашу өчен киң мөмкинлекләр булдыру. *Без барымыз да, татар галәменә яктылык кертер өчен, тәрәзә ачарга тырыштык.* Г.Исхакый. **Тәрәзә буяу** 1) *иск.* Кеше тәрәзәсе төбенә килеп хәер сорау. *Иң авыр эш – кара эшне дә Тезләнгәндәй ялынып тапкан ул. Ә еш кына тапмый һични дә, Тәрәзә буяп илгә кайткан ул.* Ш.Маннур; 2) *этн.* Яңа ел кичендә тәрәзә аша куркыныч әйбер күрсәтү

**ТӘРӘЗӘ́ БАШЫ** *и.* Тәрәзә уемының өстенә беркетелгән такта. *--- кызлар тәрәзә башларына кашагалар сузалар, тәрәзә араларына чиккән башлы озын сөлгеләр эләләр, өйнең бөтен түр башын алып торган сәкегә киез паласлар җәяләр.* Ә.Еники. *«Сылу, мин эштән кайтуга тәрәзә башларын кагып куй, дип киткән иде, – диде кияү. – Нишләптер безнең стенага кадак керми».* Ф.Яруллин

**ТӘРӘЗӘЛЕ** *с.* Тәрәзәсе булган. *Ике метр чамасы киңлектәге тимер*

*челтәрле бер тәрәзәле генә бүлмәгә килеп керделәр.* З.Зәйнуллин

**ТӘРӘЗӘЛЕК** *с.* Тәрәзәгә җитәрлек; тәрәзә ясарга яраклы. *Шуңа бер тәрәзәлек пыяла бирде.* Т.Миңнуллин. *1938 елны Голҗа шәһәрендә уйгур мәктәбен салган чакта, биш сыйныф бүлмәсенә җитәрлек агач, такта һәм ишек, тәрәзәлек материаллар юкка чыгудан, уку башланганчы мәктәпнең төзелеше бетмәү куркынычы туа.* Казан утлары

**ТӘРӘЗӘ́ ТӨБЕ** *и.* 1) Тәрәзә уемының аскы өлешенә куелган яссы агач яки таш плитә, бусага. *Түбән өйнең тәрәзә төбе җир белән тигез булганга, ишегалдында уйнап йөргән җәяүле буран койрыгы белән тәрәзәгә сыйпалып үтә.* Г.Бәширов

2) Тәрәзә яны, тәрәзәнең тышкы тирәсе. *Әбүзәр стенага елышып кына тәрәзә төбенә килде дә бүлмәдәге гәпкә колак салды.* А.Тимергалин

**ТӘРӘЗӘЧЕ** *и.* Тәрәзә рамы ясаучы яки тәрәзәгә пыяла куючы оста. *[Һадый:] Мин, үскәч, тәрәзәче булам, әни.* Д.Салихов

**ТӘРӘЗӘЧЕК** *и.* 1) Биналарда бер өлгеле кечкенә тәрәзә

2) Күзәтү, сөйләшү һ.б.ш. эшләр өчен, берәр тәрәзәдә өстәмә уеп калдырылган тишек. *Өстенә «Дежурная часть» дип язылган тәрәзәчек артында кечкенә буйлы, коңгырт күзле, мөлаем йөзле капитан утыра иде.* С.Зыялы. *[Мансур] Тагын бер тапкыр кызга сүз катып карарга теләсә дә, барып чыкмады, телефоннан сөйләшергә килгән кешеләр аны тәрәзәчек яныннан кысрыклап чыгардылар.* Г.Галиев

3) Күзәтү, карап алу, нәрсә дә булса тапшыру өчен, ишеккә уелган һәм ябылып куела торган ачыклык. *Тимер ишектә мунча төнлегеннән аз гына зур булган тәрәзәчек бар. Ул да тимер капкачлы.* С.Поварисов. *Ишектәге тәрәзәчек ачылган, анда ниндидер бер егетнең ябь-яшь йөзе күренә.* З.Зәйнуллин

4) Яктылык үтә алырлык бәләкәй тишекләр. *Мичтә дөрләгән ялкынга, самавыр торбасы тәрәзәчекләреннән күз кыскан кузларга карап утырырга ярата ул.* Ф.Мөслимова

5) *информ.* Монитор экранында аерым рамга алып күрсәтелгән өстәмә мәгълүмат. *Сайтта «Шәхси кабинет» булдырып, картада закон бозу урынын күрсәтәбез, тәрәзәчектә адрес пәйда була, үзебез төшереп алган сәүдә объектлары фотосурәтләрен урнаштырабыз.* Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе

**ТӘРӘККЫЙ** *и. гар. кит.* **1.** Алга китеш, үсеш, камилләшү; алгарыш, прогресс. *Минемчә, хәзер тәрәккый өчен иң кирәкле эш – --- һәр хәрәкәтемездә хөр булмактадыр.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Алга киткән, алдынгы, үскән, камилләшкән. *Милләтебез аңлы, белемле, тәрәккый милләтләрнең берсе булачак!* Ф.Яхин. *Тургеневның тәрәккый карашлы геройларыдай, ул [Мансур Аллаяров], нинди генә михнәтләргә юлыкса да, халыкка хезмәт итү уеннан ваз кичмәслеген белә.* Р.Рахман

**ТӘРӘККЫ́Й ИТҮ** *ф. кит.* Алга китү, үсү, камилләшү. *Әмма фән дөньясы бик тиз тәрәккый итә.* Казан утлары

**ТӘРӘККЫЙ КЫЛУ** *ф. кит. к.* **тәрәккый итү**. *Татарстан гел шулай тәрәккый кылсын, бай булсын.* Казан утлары

**ТӘРӘККЫЙПӘРВӘР** *и. гар.-фар. кит.* Иҗтимагый тормышта алга китүне, үсүне, алгарышны яклаучы, камиллеккә омтылучы кеше. *Аларга татарның чәч үстерүе дә, европача киенүе дә, тәрәккыйпәрвәр булуы да ошамый.* С.Поварисов

**ТӘРӘККЫЙПӘРВӘРЛӘНҮ** *ф. иск. кит.* Тәрәккыйпәрвәр булу яки тәрәккыйпәрвәр булып кылану. *Юкка ул [Сабир], тәрәккыйпәрвәрләнеп, хатынын ирләрдән качырмады.* Г.Газиз

**Тәрәккыйпәрвәрләнеп йөрү** Үзен һәрвакыт тәрәккыйпәрвәр итеп күрсәтергә тырышу

**ТӘРӘККЫЙПӘРВӘРЛЕК** *и. кит.* Тәрәккыйпәрвәр булу. *Тәрәккыйпәрвәрлек фикере нигезендә рус кызлары белән тормыш кору кемнәрдәдер яклау тапса, революциядән соңгы елларда, интернационализм идеясен тормышка ашыру максатыннан, катнаш никахлар хуплана башлый.* Л.Газизова

**ТӘРӘККЫЙЧЕ** *и. кит.* Тәрәккый, алгарыш яклы кеше. *Бу чорда ул язучыны җәдидчелек, тәрәккыйче милләтчелек идеяләре белән сугарылган әдип буларак бәяли.* Р.Рахман

**ТӘРӘККЫЯТ** *и. гар. кит.* Алга китеш, үсеш, алгарыш. *Яңалык нәрсәдә чагыла соң, дигән сорау туа: киемдә, үз-үзеңне тоту әдәбендә, белемгә, атаана, кеше фикеренә, милли сәнгать, әдәбият, тәрәккыят, халыкның яшәү дәрәҗәсенә һәм башкаларга мөнәсәбәттә...* Р.Рахман

**ТӘРӘП** *и. диал. к.* **тәрәш** (*2 мәгъ.*)

**ТӘРӘПЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **тәрәшләү**

**ТӘРӘТ** *и. гар.* 1) *сөйл. к.* **тәһарәт**. *Өйгә кайткач, тәрәт алып, өйләне укып ята идем.* С.Җәлал. *[Ул] Юкә кисүчеләр арасындагы берничә абруйлырак крәстияннәргә карап, мәчет карты рәвешендәрәк: – Җәмәгать, аетне монда укырбыз, тәрәтләрне чын күңелдән алып укысак, Аллаһ Тәлә монда укыганда да кабул итәр, – диде.* Һ.Такташ

2) Кеше тизәге. *Еш кына эч китә, эч ката, тәрәттә кан күренә, арт юлда авыртулар хасил була.* А.Шәйхразиева. *Баланың тәрәтен тота алмавы соңгы елларда бик еш күзәтелә икән. Моның сәбәбе – памперс, дип саный табиб.* Ватаным Татарстан

**ТӘРӘТДЕТ** *и. гар. иск.* Теге яки бу эшне эшләргә икеләнү, бер ныклы карарга килә алмау. *Илаһи, бу беренче адымымда, беренче мәктүбемне язуда, җибәрүдә, тегеннән җавап килгәнче үткән озын төннәрдә, яшь йөрәкнең кичергән шөбһәләрен, тойган тәрәтдетләрен, дулкыннарын, бертуктаусыз алмашып торган ышану, шатлану һәм көенүләренең ни мәртәбәгә җиткәнен, бер Ходай, үзең генә белерсең...* Г.Ибраһимов

**ТӘРӘТДЕ́Т ИТҮ** *ф. иск. кит.* Нинди дә булса эшне эшләргә икеләнү, ныклы бер карарга килә алмый тору. *[Габделгалләм] Бераз ишек төбендә тәрәтдет итеп торганнан соң, ашыгычашыгыч кереп тә китте.* Ф.Әмирхан

**ТӘРӘТДЕТЛӘНҮ** *ф. иск. кит. к.* **тәрәтдет итү**

**Тәрәтдетләнә башлау** Тәрәтдет халәтенә керү. *Моннан соң аның күңеле*

*тәрәтдетләнә башлап, ни эшләргә белми, ике арада кала башлады.* М.Гафури

**ТӘРӘ́Т ИТҮ** *ф. к.* **тәрәтләү**. *НКВД хезмәткәрләре, йомшак күңеллелек күрсәтеп, вагон идәннәренә салам китереп җәйделәр, тәрәт итү өчен тәпәннәр куйдылар.* Я.Шәфыйков. *Юындыргач яки тәрәт иткәч үк подгузник кидереп куймагыз, җиңелчә массаж ясагыз, --- подгузник кидерер алдыннан, баланың йомшак җиренә саклагыч крем сөртегез.* Ватаным Татарстан

**ТӘРӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тәрәтләү**

2) *сөйл.* Тәһарәт алу, тәһарәтләнү

**ТӘРӘТЛӘ́Ү** *ф.* Олы хаҗәтне үтәү, тышка чыгу

**ТӘРӘТХАНӘ** *и. гар.-фар.* Тәһарәтханә. *Ишек аша ишек, каравыл аша каравыл узып, ул ишегалдына чыкты, тәрәтханәгә керде, төнлектән тышка бакты. Батырның йөрәген курку билән алды: ханә арты тулы мылтыкчылар иде.* Р.Батулла

**ТӘРӘЧ** *и. рус зоол.* Тәрәч балыклар семьялыгыннан салкын диңгезләрдә тереклек итә торган, эре сөякле, көрән яки яшькелт сырты тимгелләр белән капланган балык, промысел объекты; *русчасы:* **треска**. *Шешәләргә ямь биреп, карауга авыздан су китерә торган кара, кызыл икра банкаларын, тәрәч бавырын, крабларны да әйтсәң, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның нинди бәхетле икәне, шәт, аңлашыладыр...* А.Гыйләҗев. *Садри икенчеләй стаканны хутка җибәргәннән соң, тәрәч балыгының соңгы кисәкләрен чүпли иде инде.* К.Кара

**ТӘРӘ́ЧСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Салкын диңгезләрдә яши торган эре сөякле тәрәч, навага, пикша кебек балыкларны берләштергән отряд. *Навага – тәрәчсыманнар отрядыннан төче сулыкта яшәүче бердәнбер балык төре.* Биология

**ТӘРӘ́ЧЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Тәрәчсыманнар отрядына караган, сайда, минтай һ.б.ш. балык ыруларын берләштергән семьялык. *Жумба ул тәрәччәләр семьялыгына керә.* Г.Хәсәнов

**ТӘРӘШ** *и.* **1.** 1) Эрләү өчен тетелгән җитен яки киндер сүсе. *[Дүхәт мулла] Эрләп бетмәгән тәрәш кебек сакаллы иде.* Х.Кәрим. *Кушыла алмый Сагышлы хәтер. Аерым икесе: Таралган тәрәш...* Б.Рәхимова

2) Сүсне тарау, тетү өчен, очында тарагы булган агач эш коралы. *Анда үзенең бер дә бетмәс талкы, тәрәш, каба кебек «җитештерү коралларыннан» арына алмыйча мәңге йөгереп йөрүче Наһар түти бар.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Сүс эрләү өчен кулланылган. *Клара, күзен ачкач, тагын «ак» чоланның шүрлегендә һәм чөйләрендә аңа исемнәре дә билгеле булмаган әйберләрне – йон кабасын, тәрәш таракны, каен тузыннан теккән кечкенә тубалны, кипкән шомырт белән тулы агач шаваны күрде.* Ә.Еники. *Якуп абзый – гомер буе өрәңгә белән каеннан чәч тарагы, каба, тәрәш тарак тешәп көн иткән кеше.* Г.Бәширов

**ТӘРӘШЛӘНҮ** *ф.* Тәрәшле каба аша үткәрелү; тетелү. *Тәрәшләнгән сүс*

**ТӘРӘШЛӘ́Ү** I *ф.* Сүсне, йонны һ.б.ш.ны тәрәшле кабада тарау, тәрәш тарагы аша үткәрү, тетү. *Йон тәрәшләгәндә җырлый иде ул бу җырны ---.* Сөембикә

**Тәрәшләп бетерү** Тәрәшләүне тәгәлләү; тулысынча тәрәшләү. *– Йонны тәрәшләп бетерүгә, чәй эчеп алырбыз, – диде әби, елмаеп.* Р.Вәлиева

**Тәрәшләп кую** Алдан яки тиз арада тәрәшләү. *Барысын да бүген үк тәрәшләп куйсаң, эшең җиңеләя инде.* Р.Нуруллина

**Тәрәшли бару** Рәттән барысын да тәрәшләү. *Әнисе чүбеннән чистарткан йонны кызы тәрәшли бара*

**Тәрәшли башлау** Тәрәшләргә тотыну. *Тәрәшли башлаганны гына көткәндәй, өйдә ут сүнде, бөтен дөньяны караңгылык каплады.* Р.Вәлиева

**ТӘРӘШЛӘ́Ү** II *и. диал. к.* **тәрәш** (*2 мәгъ.*). *[Кызларның] Өлкәне тәрәшләү белән йон яза, уртанчысы кабада җеп эрли дә орчык әйләндерә, кечкенәсе көмеш энәләр белән шәл бәйли.* Н.Каштанов

**ТӘРӘШЛЕ** *с.* **1.** 1) Тәрәш белән эшкәртелгән, эрләү өчен тетелгән, таралган. *Җеп орчык ярдәмендә тәрәшле сүстән эрләнгән, орчык тизрәк әйләнсен өчен, аңа балчык яки таш киерткәннәр.* Б.Хәмидуллин

2) Тәрәше (*2 мәгъ.*) булган. *[Әни] Салкынчарак урынга – җир идәнле өйалдыбыздагы сәкегә – тәрәшле каба көйләгән дә йон эрләп утыра.* В.Нуруллин. *Киндер өчен дә әле, иң элек, сүсне җыярга, талкырга, аннары тәрәшле таpактан тарта-тарта җирләргә кирәк, шуннан соң гына станда сугалар, селтәләргә сала-сала агарталар, су буена алып төшеп, бәләкле-бәләкли юалар, буяу тапсалар, киндерне маналар...* Туган як

**2.** *и. мәгъ. к.* **тәрәш** (*1 мәгъ.*). *Башлаган тәрәшлесен эрләп бетерә дә алъяпкычындагы чүпне идәнгә селки.* И.Гази

**ТӘРБИЯ** *и. гар.* 1) Тиешле әдәп кагыйдәләренә, этик һәм эстетик күнекмәләргә өйрәтү, белем бирү эшчәнлеге. *[Хак Тәгалә] Миңа да күп кенә нәрсәләрне төшендерде: хакыйкатьне дөрес итеп, кызартмыйча язарга кушты. Алдашу тәрбия чыганагы түгел икән.* Н.Хәсәнов. *Менә әни шулай дип әйтмәгән булса, каян белер идек кунакчыллыкның шундый нечкәлекләре дә барлыгын һәм бу хәлнең олы тәрбия мизгеле икәнлеген дә.* Н.Кәримова

2) Саулык-сәламәтлекне, физик камиллекне саклау, яхшырту эшчәнлеге. *Кыш көне ике бармак калынлыгындагы имән чаңгыда йөрүдән башка бер дә тән тәрбиясе кайгыртылмаган.* М.Мәһдиев. *Кыз баланың эчке дөньясын, рухи халәтен әнисе кайгыртса, физик тәрбия әтисе җилкәсенә төште: кышын чаңгыда, тимераякта шудылар, җәй көне дә эш табыла иде...* Р.Кәрами

3) Өйрәтү нәтиҗәсе буларак үзләштерелгән аң-белем, тиешле культура, әдәп-әхлак кагыйдәләре. *Фатыйма, Касыйм каласында туып Мәскәүдә үссә дә, Аллаһы Тәгаләне һәрдаим искә алырга күнеккән, затлы тәрбиягә ия кыз иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Минем кызым – яхшы тәрбия алган инсафлы бала!* З.Хәким

4) Кемне яки нәрсәне дә булса матди яктан тәэмин итү, кайгырту, тиешле шартлар тудыру; карап тору, үз хисабына асрау. *Зәки миңа яхшы тәрбия кирәк дип тапты: печән җыеп, кукуруз сабак-*

*ларыннан шалаш кордырды да мине урынга яткырдылар, якында гына яшәүче малайлар өйләреннән суган, пешкән бәрәңге, ипи алып килделәр.* Р.Газиз. *Ире Тәбрик: «Әнкәйне үзебезнең янга алып килик, аңа тәрбия кирәк», – дигәч, бишкуллап риза булды.* Ф.Яруллин

**ТӘРБИЯВИ** *с. гар. кит.* Тәрбия бирә торган, тәрбия максатларына ярашлы, тәрбиягә ярдәм итәрлек. *Ул да булмый, ниндидер профессор Мещеряков эксперименты буенча бәхәс, профессор Божович теориясе буенча тәрбияви дәрес үткәрмәкче, тагын әллә ниләр.* В.Имамов

**ТӘРБИЯ́ ИТҮ** *ф. к.* **тәрбияләү**. *Мин берникадәр балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итүне беренче максат итеп тотсам да, --- әдәбият Россия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме, дигән өметем дә бар иде.* Г.Тукай. *Чөнки морза тулпарын җаны кебек күрә, күз карасыдай саклый, тәрбия итә.* М.Әмирханов

**ТӘРБИЯ́ КЫЛУ** *ф. к.* **тәрбияләү**. *Ярый, җирнең шәбен эләктергәнсең икән, эшкәрт син аны, кадерләп тәрбия кыл.* Ф.Садриев. *Мәнә сезгә берәр үрдәк, күктәге ай бер мәртәбә ябыгып тулышкан вакыт эчендә аларны тәрбия кылыгыз.* Г.Гыйльманов

**ТӘРБИЯЛӘНҮ** *ф.* Тәрбия алу, тәрбия ителү. *Икенче бер папкада – Крупская, Клара Цеткин, парашютист ханымнар һәм башкалар турында истәлекләр; Галия шулар үрнәгендә тәрбияләнә, тәрбияли.* Р.Рахман. *Мулла гаиләсендә миһербанлык рухында тәрбияләнгән намуслы шәхес буларак, Ибраһим иң җаваплы, үзе өчен хәтәр мизгелләрдә дә принципиальлек күрсәтергә тырыша, гаделлек сагында торырга омтыла.* Р.Әмирхан

**Тәрбияләнеп килү** Элек-электән, даими тәрбияләнү

**ТӘРБИЯЛӘ́Ү** *ф.* 1) Даими рәвештә тиешле әдәп-әхлак кагыйдәләренә, гадәтләргә, күнекмәләргә өйрәтү, аңбелем бирү. *Балаларына алар заманча белем бирергә, аларны зыялы кешеләр итеп тәрбияләргә омтылалар.* Ф.Мөслимова

2) Кемнең дә булса үсешенә, фикер йөртүенә, тойгыларына даими йогынты ясау. *Шулай ук без --- киң хезмәт массасы арасындагы төрле ятышсыз якларны төзәтү, тәрбияләү теләге белән көлке әсәрләр язарга тиешбез, чөнки көлү – тәрбияләү методының иң көчлеләреннән [берсе].* М.Җәлил

3) Кемне дә булса билгеле бер гадәткә, холык-фигыльгә өйрәтү, күнектерү, гадәтләндерү, нинди дә булса сыйфат, хис, үзлек бирү, йоктыру. *Тугры ирнең тугры хатыны, күп балалы газиз ана булып, балаларымны намуслы, иманлы итеп тәрбиялисем килә.* Г.Галиева

4) Тиешле яшәү шартлары тудырып асрау, багу. *Авыл халкы үзләре тәрбияләп тергезгән кошны кул болгап, хәерле сәфәр теләп озатып кала.* А.Тимергалин. *Сугышка кадәр язгы чәчүдә эшләргә тиешле атларны бер ай беркая да җикмичә шәпләп тәрбиялиләр, ял иттерәләр иде.* В.Нуруллин

**Тәрбияләп карау** Сынау максаты белән тәрбияләү. *Мәнә тагын бер тапкыр тәрбияләп карыйк!* Н.Кәримова

**Тәрбияләп килү** Элек-электән, даими рәвештә тәрбияләү. *Авыз иҗаты әсәрләре борынгы заманнардан бирле кешеләрдә туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт, хезмәт сөю, һөнәргә, белемгә омтылу, батырлык, гаделлек, сабырлык, тыйнаклык, юмартлык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләп килде.* К.Идрисова

**Тәрбияләп тору** Һәрвакыт тәрбияләү. *Әнкәйне мин ел саен ике-өч мәртәбә үз яныма чакырып, кунак итеп, тәрбияләп тордым.* Г.Гыйльманов. *[Таһир Якуповның] Каберен карап, тәрбияләп торам.* Татарстан яшьләре

**Тәрбияли башлау** Тәрбияләргә керешү. *Тизрәк үссеннәр, симезрәк булсыннар дип, Равил энем белән без аларны [бәрәннәрне] аеруча нык тәрбияли башладык.* В.Нуруллин

**Тәрбияли килү** *к.* **тәрбияләп килү**. *Яшьләрне гомер-гомергә өлкәннәр тәрбияли килгән.* М.Хуҗин

**ТӘРБИЯЛЕ** *с.* **1.** 1) Тиешле тәрбия алган, әдәп-әхлак кагыйдәләрен яхшы белгән, үзен шул кагыйдә кысаларында тоткан. *Шулай итеп, бер-берсенә ярдәмләшә торган, олыны – олы, кечене кече иткән тәрбияле, яхшы балалар үстерде Фәридә.* Н.Кәримова. *Мин аңа бик рәхмәтлемен, ул – бик ихлас, театрга искиткеч бирелгән, тәрбияле, акыллы кеше.* Ф.Мөслимова

2) Тиешле шартларда тәрбияләнгән, бөтен шартын китереп асралган; тиешенчә каралган, тиешле шартлар тудырылган. *Вокзал алдындагы бик матур вә тәрбияле бакча һәрбер юлчының күңеленә истифһам галәмәте төшерә.* Ф.Әмирхан. *Тәрбияле йомшак урында йокыбыз канганчы йокладык.* М.Яһудин

**2.** *рәв. мәгъ.* Әдәп-әхлак кагыйдәләренә туры китереп. *Зифа буйлы, үз кадерләрен, үз кыйммәтләрен яхшы аңлаучы гарәп хезмәткәрләре үзләрен искиткеч тыныч, тәрбияле тота.* Ә.Дусайлы

**ТӘРБИЯЛЕЛЕК** *и.* Тәрбияле булу сыйфаты. *Мөгаллим баласы башкалардан иҗтиһад, уңганлык, тәрбиялелек белән аерылып торырга --- тиеш кебек кабул ителгән.* И.Нуруллин

**ТӘРБИЯСЕЗ** *с.* **1.** Тиешле әдәп-әхлак тәрбиясе алмаган, кабул ителгән әдәп-әхлак кагыйдәләренә буйсынмый, аларны сакламый торган, үзен тупас, әдәпсез тоткан. *Начар гадәтле, тәрбиясез егетләр эше бу!* М.Мәһдиев. *Бу кимсенүгә түзеп тора алмыйча, бар ярсуларын, яшәүгә омтылышларын канат итеп, чәчәкләр тәрбиясез малай аяк астында тапталудан ничек тә котылмакчы булалар.* Г.Гыйльманов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Фактны дөрес тотып алгансыз: әйе, кызганычка каршы, кино вакытында тәмәке тартучы тәрбиясезләр очраштыргалый әле бездә!* В.Нуруллин

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиешле әдәп-әхлак тәрбиясе күрмичә. *Мәнә бит ул тәрбиясез үскән сала йолкышы!* М.Юныс

2) Әдәп-әхлак кагыйдәләрен бозып, әдәп сакламыйча. *Тәрбиясез кылану*

3) Кайгыртучысыннан, караучысыннан мәхрүм булып. *Мәнә мин әйткән әлеге аккоштай йорт тәрбиясез кала, ди.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТӘРБИЯСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Тәрбиясезгә әйләнү, үзен тупас, әдәпсез тота башлау, кабул ителгән тиешле әдәп-әхлак

кагыйдәләрен бозу. *Җитәр! Ничек син болай тәрбиясезләнәсең? Тилердеңме әллә?* М.Фәйзи

**Тәрбиясезләнә бару** Торган саен ныграк тәрбиясезләнү

**Тәрбиясезләнә төшү** Тагын да тәрбиясезләнү

**Тәрбиясезләнеп алу** Бераз тәрбиясезләнү

**Тәрбиясезләнеп бетү** Тәмам, бик нык тәрбиясезләнү

**Тәрбиясезләнеп китү** Соңгы вакытларда сизелерлек тәрбиясезләнү

**Тәрбиясезләнеп тору** Әле, хәзер, күз алдында тәрбиясезләнү

**ТӘРБИЯСЕЗЛЕК** *и.* Тәрбиясез булу, әдәпсезлек, холыксызлык. *Хәлсез хастадан икенче тапкыр бер үк сөальне кабатлату хәттин ашкан бер тәрбиясезлек булса да, әмир Муса кыяфәтенә ризасызлык чыгармады.* Р.Батулла. *Әмма ике йөрәк тергезеп килгән мәхәббәт ялкынына су булып сибелү дә хата һәм тәрбиясезлек икәнлеген белә.* Ф.Яхин

**ТӘРБИЯЧЕ** *и.* 1) Тәрбия эше белән шөгыльләнүче махсус хезмәткәр. *Мәхмүт абыйсы – мәктәп директоры, хатыны Кәшифә апа – кызлар торагында тәрбияче.* Р.Газиз. *Безгә якында гына урнашкан балалар бакчасына тәрбияче кирәк икән.* Р.Хәбибуллина // Нәрсәгә булса да өйрәтүче, нинди дә булса сыйфатларга өндәүче зат. *«Кешегә усаллык итмә!» Нинди кыска сүз! Бу сүзе белән Рәсүлуллаһ һәрбер адәмне үзенә үзе өчен юл күрсәтүче һәм тәрбияче булырга тиешлеген белдерә.* Р.Фәхреддин. *Әти кеше, тәрбияче... Каян килгән бу осталык? Каян таныш аңа тәрбия эше?* Ә.Низамова

2) Ашатып-эчереп, карап, тәрбияләп торучы кеше; тиешле шартлар тудырып, кайгыртып торучы зат. *Мине карап үстергән тәрбияче әби гел әйтә иде: «Сез ике туган булгансыз, онытма, берегез малай булган», – ди иде.* Г.Гыйльманов

**ТӘРБИЯЧЕЛ** *с.* Тәрбия бирә торган, тәрбияләү максаты куйган. *Совет чоры әдәбиятының беренчел бурычы укучысына тәрбиячел мөнәсәбәт булган*

**ТӘРБИЯЧЕЛЛЕК** *и.* Тәрбиячел булу

**ТӘРЕ** *и.* 1) *бор.* Исламга кадәрге мәҗүсилек чорында баш илаһ, күк дөньясының башлыгы; тәңре. *Шулай итеп, тәре «мәҗүси илаһ, пот; әшәке җан» һәм мөселман Тәңре икесе дә бер үк сүзгә – төрки, монгол халыкларының «беренче» баш илаһы, «күк дөньясының башлыгы» булган «тәңир» сүзенә кайтып кала.* Р.Әхмәтьянов

2) Христианнар илаһ санап табына торган Гайсә галәйһиссәламнең яки берәр изгенең сурәте төшерелгән такта; икона. *Түрдәге сул почмакта тәре, астарак Матрёна түтәйнең яшь вакытта ире белән төшкән фотосурәте эленеп тора.* З.Мәхмүди

3) Христианлык билгесе буларак үзара турыпочмак ясап кисешкән ике таяктан гыйбарәт дини табыну әйбере, шуның символы; хач һәм аның төрле гәүдәләнеше. *Рязань кызы, беренче онык тугач та, аны Бауман урамындагы чиркәүдә чукындырып, поптан Анастасия исеме куштырды һәм баласының муенына алтын тәре асты.* Н.Гыйматдинова. *Изге бабаларыбызның кабер ташларыннан салынган чиркәүнең тәресенә яшен чатыр-чотыр бәрә, ә нигездә яткан ташлардагы гарәп язулы чигешләрне эре яңгыр тамчылары елый-елый укыйлар...* Б.Рәхимова

4) Әвернә формасында үзара кисешкән ике сызыктан гыйбарәт билге, галәмәт. *Бу бит тәре түгел, кушу галәмәте, ди.* Г.Бәширов. *Нәкъ шулвакыт каяндыр полк врачы Нина Андреевна килеп чыкты, ул уң кулына сыртына тәре сугылган сумка тоткан иде.* С.Поварисов

5) Шул рәвештәге орден яки медаль. *Гаскәр килә икән, дигәч, Акбарыш баба, солдаттан кайткан киемнәрен киеп, гомер такмаган өч тәресен түшенә кадап, мәйданга китте.* Р.Батулла. *Кыскасы, яхшылык, батырлык эшләгән мөселман хөкүмәт тарафыннан тәре ала.* Я.Шәфыйков

6) *махс.* Бер-беренә аркылы куеп беркетелгән агач яки тимерләрдән торган деталь яки җайланма; әвернә. *[Арбаңның] Тәресе иртәгә өлгергән булыр.* Ф.Хөсни

7) Уен картасының сабаклы өчьяфрак рәсеме төшерелгән кара масте; треф. *Мирвәли кулына килеп кергән тәре тузына, чынлап та, ашык-пошык кына бер сүз тырналган иде: «Стрелка».* Г.Гыйльманов

8) *күч. гади с.* Тиргәү, сүгү сүзе буларак кулланыла. *Хәзер беребезгә дә рәт юк, икебезне дә туздырды, тәре!* Р.Батулла. *Безнең хәлне аңлагыз инде, шагыйрь тәреләр.* Ф.Яруллин

◊ **Тәресенә кату** Карышып нык киреләнү, үҗәтләнеп үзсүзләнү

**ТӘРЕ БАГАНАСЫ** *и.* 1) Христиан торак пунктларына кергәндә, юл буена яки эчтә уртадагы мәйданга куелган хач һәм аңа Гайсә галәйһиссәлам яки башка изгеләр сурәте беркетелгән багана. *Өч манаралы костёллар, юлларда бик еш очраган тәре баганалары, дугасыз җигелгән атлар, хәтсез озын олау арбалары, --- уйсулыклар, сыртлар, ташлы һәм кызгылт комлык җир – барысы да Польша җиренең үзенчәлеге иде.* А.Расих

2) *күч. гади с. к.* **тәре** (*8 мәгъ.*). *Имгәтммәдем, кәнишне, ярата идем тәре баганасын, тотып өч мәртәбә селеккәнмендер.* Н.Гыйматдинова

**ТӘРЕ́ БҮЛМӘСЕ** *и. дини* Чиркәүнең гомуми бүлмәдән иконалар урнашкан стена белән аерылган һәм зур биек өстәл куелган көнчыгыш өлеше

**ТӘРЕ́ ЙӨРТҮЧЕ** *и. тар.* Тәре явында катнашучы кеше. *Уку-язу – Христоска каршы бару, дигән дини фанатизм байрагы астында тәре йөртүче католиклар тарафыннан максатлы рәвештә китапларны, уку йортларын ачыктан-ачык юк итү, яу-походлар вакытында акыл ияләрен асу-кисү, яндыру кебек коточкыч афәт-золымы берничә гасыр буена бара.* М.Галиев

**ТӘРЕЛӘНДЕРҮ** *ф. туп.* Акайту, зур итеп ачу; ялтырату (күзләрне). *Габделхак абзый күзен тәреләндереп аяк астына караса, чыннан да, канатлары каерылган бу мескен кош – казларының инәсе икән.* Ф.Яхин. *Инде котылдым бугай дип кенә барадырыем, тәки күзеңне тәреләндереп килеп җиттең бит, ә!* В.Нуруллин

**ТӘРЕЛӘНҮ** *ф. туп.* Киресен эшләү, начар якка китү. *Кемнәрдер гомерен мал җыеп, кеше алдап, кеше талап яши, масая, тәкәбберләнә, милләт*

*мәнфәгатен сату хисабына кәнәфиен саклый, түрәләнә, тәреләнә.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**ТӘРЕЛЕ** *с.* 1) Тәре рәвешендәге, тәредән торган. *Меңнәрчә кешене зинданнарда череткән, юл буендагы тәреле баганаларга кадаклаткан, --- тәмам иблискә әверелгән Нерон, әҗәле килүен сизгәч, ни кылырга белми, кай тарафларга чыгып качарга белми йөди.* М.Хәбибуллин. *Тәреле урдинны Әмәмәт каядыр яшерде.* З.Зәйнуллин

2) Тәресе булган, тәре сурәте төшерелгән. *Кара тәреле самолётлар нарат башларына тияр-тимәс кенә очып йөрделәр.* М.Мәһдиев. *Яралыларны утырткан кызыл тәреле арбалар гына ара-тирә күренгәләп китә.* А.Шамов

**ТӘРЕЛЕ́ ЙӨРЕШ** *и.* Башлыча бәйрәм киемнәрендә, иконалар, тәреләр, байраклар тотып, билгеле маршрут буенча үткән дин тотучылар хәрәкәтеннән гыйбарәт христианлык йоласы; хачлы йөреш. *Дини чарадан соң, сәгать 11 тулганда, йөзләрчә кеше катнашында Казан кирмәненнән башлап Крестовоздвиженский чиркәвенә таба тәреле йөреш уздырылды.* Р.Шакир

**ТӘРЕ́ ПОХОДЫ** *и. тар.* 1) *к.* **тәре явы**. *Әнә Рум папасы католиклар чиркәве исеменнән Аурупадагы инквизиция өчен дә гафу үтенә, гарәпләрдән тәре походлары ясаганга да ярлыкау сорый.* Р.Зәйдулла. *Билгеле булганча, Казанны яулап алу походын Мөдһиш Иван тәре походы формасында оештыра.* Р.Фәхретдин

2) *күч.* Берәр нәрсәгә каршы оештырылган пропагандалы көрәш кампаниясе. *[Фашистлар:] Берләшик без изге берлеккә, Оештырыйк тәре походын, – [диләр].* Ә.Фәйзи

**ТӘРЕ́ СУГЫШЫ** *и. тар. к.* **тәре явы**. *Үсамә бин Мункыйз, Сурия гарәбе, тәре сугышлары вакытында яшәгән.* Н.Фәттах

**ТӘРЕ́ ТАБАГАЧЫ** *и.* 1) Чиркәү байрагын күтәреп йөртә торган тәресыман сап

2) *туп. к.* **тәре** (*8 мәгъ.*). – *Зират өсте булмаса, әйтер идем инде мин сиңа, тәре табагачы! – дип мыгырдады Мөҗип.* Р.Батулла

**ТӘРЕЧЕ** *и.* Дини демонстрацияләрдә тәре күтәреп йөрүче кеше. *Тәречеләр катына урамга чыгучы шәкертләргә бойкот булачак.* К.Тинчурин

**ТӘРЕ́ ЯВЫ** *и. тар.* XI–XV гасырларда Көнбатыш Европа феодалларының башта Иерусалимны мөселманнар кулыннан алу, католик динен тарату өчен, соңрак башка, башлыча дини максатлар белән Якын Көнчыгыш, Төньяк Африка һ.б.ш.ларга оештырган сугышлары. *Аурупалыларның тәре явына каршы Мисыр һәм Сурияне берләштергән хаким, милләте белән көрд, гаскәр башлыгыннан хакимлеккә күтәрелә.* Г.Исхакый. *Брейвик үз белдерүендә Европадагы мөселманнарга каршы тәре яулары башларга чакыра.* Н.Акмал

**ТӘРҖЕМАН** *и. фар.* 1) Тәрҗемәче, тылмач. *Олуглар тирәсендә берничә ел тәрҗеман булып кына йөрү җитмидер.* К.Насыйри. *Аның русча ярыйсы гына сөйләшә алуын, ә төрек, гарәп, фарсы телләрен су урынына эчүен күреп, тәрҗеман итеп эшкә алуны хуп күрделәр.* З.Мурсиев

2) Нинди дә булса фикерне, максатны аңлатуда, җиткерүдә арадашчы, корал; аңлатучы, пропагандалаучы. *Мәсәлән, хиссият тәрҗеманы булган сүзләрдән – хикмәт, хыялый шигырьләрдән – хакыйкать, анчак күңел ачар өчен генә сөйләнгән мәнзумәләрдән нечкәлек эзләү мөнәккыйдьлек улмас.* М.Гафури

**ТӘРҖЕМАНЛЫК** *и.* 1) Тәрҗемәче булу шөгыле, эше; тылмачлык. *Безнең кавем тәрҗеманлыкка элек-электән үк өстенлекле игътибар биргән, хәтта әлеге вазифага ныклап алынучы мирзалар да булган.* З.Мансуров. *Аның [Л.Хәмидуллинның] тәрҗеманлык тырышлыгы белән казакъ язучыларының повестьлары да («Җәйләүдә», 1993), казакъ халык әкиятләре дә («Сыбызгы сере», 1996) аерым басмаларда дөнья күрә.* Казан утлары

2) Арадашлык

**ТӘРҖЕМАНЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Тәрҗеман вазифасын үтәү. *Фракциямез, Вакытлы комитетымыз үзенең мәгълүматы, тәҗрибәсе белән берсен берсе белми торган мөселман халкы белән түрәләр арасында васитачылык, тәрҗеманлык итмәсә, итә алмаса, ике тараф өчен дә кирәкмәгән мәшәкатьләр тууы табигый эштер.* Г.Исхакый

**ТӘРҖЕМАНЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **тәрҗеманлык итү**. *[Ул] Урта Азия һәм казакъ ханнары белән рус патшалары арасында тәрҗеманлык һәм арадашлык кылып, генерал дәрәҗәсенә күтәрелгән татар морзасы Котлугмөхәммәт Тәфкилев.* Г.Ибраһимов

**ТӘРҖЕМАНЧЫ** *и.* XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында Кырымда чыккан «Тәрҗеман» газетасының мәсләген яклаучы кеше; төрки телләрне үзара якынайту идеясен, максатын алга сөргән төркем, юнәлеш тарафдары. *«Тәрҗеман»ның мәсләке әлбәттә яхшыдыр, чөнки аның теленчә укып язган кемсәләр госманлы төрекчәсенә һәм якынлашачак, вәләкин тәрҗеманчы улмак өчен, мотлакан, ислам мәдрәсәләрендә сәнәләрчә ятып дәрес күрмәгә ихтыяҗ вардыр.* Г.Камал

**ТӘРҖЕМӘ** *и. гар.* **1.** 1) Бер телдә әйтелгән, язылган фикерне икенче тел чаралары белән әйтеп яисә язып бирү, бер телдә әйтелгән яки язылганны икенче телгә күчерү эше. *Хәтта әле әдәби тәрҗемә өлкәсендә азау тешләр яргач та, берәр әсәрдә шигъри тәрҗемәне дә үзем үк башкарган очракларда, шагыйрь кисәкләре акыл сатмакчылар.* К.Миңлебаев

2) Бер телдәге мәгълүматның икенче тел чаралары ярдәме белән бирелгән язма яки сөйләмә текст; тәрҗемә ителгән нәрсә. *Мин, Истанбулга барып, җыен яңа әдәбият, шулар җөмләсеннән оригинал, тәрҗемә, төрле театр китаплары төяп алып кайтам.* Г.Камал. *Китап тышлыгындагы кәгазьләр арасыннан әлеге тәрҗемә дә килеп чыкты.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Бер телдән икенче бер телгә күчерелгән, аударылган. *Рус теленнән тәрҗемә ителсә дә, тәрҗемә әсәрләр бик-бик сирәк очракта гына ирешә торган халык мәхәббәтен яулады.* Ю.Сафиуллин

**ТӘРҖЕМӘ́ ИТҮ** *ф.* Берәр телдә әйтелгән яки язылганны икенче бер телгә күчерү, шул тел чаралары белән бирү. *Кайбер үҗәт адәмнәр, Коръән*

*сүзләрен әнә шулай турыдан-туры гына тәрҗемә итәргә кирәк, ди.* Р.Батулла. *Ул чакта мин Герценның «Үткәннәр һәм уйлар» исемле китабын украин теленә тәрҗемә итеп йөри идем.* М.Маликова

**ТӘРҖЕМӘ́И ХӘЛ** *и. гар.* Кемнең дә булса тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында төп мәгълүмат; биография. *Тукай дустыбыз әйтмешли, киләчәктә безнең тәрҗемәи хәлебезне энәсеннән җебенә кадәр өйрәнерләр әле.* И.Юзеев. *Аңа Җәүдәтнең киләсен алдан хәбәр итеп куйганнар иде булса кирәк, ул сорау-фәләнне көтмичә, кыска гына итеп, үзенең тәрҗемәи хәлен дә сөйләп алды.* А.Хәлим

**ТӘРҖЕМӘ́И ХӘЛЧЕ** *и. иск.* Берәр кешенең тормыш юлын, эшчәнлеген тасвирлап язып бирүче; биограф. *Тәрҗемәи хәлчеләр яшь сабыйның хаклы да, хаксыз да таяк ашаганын язалар.* Г.Ибраһимов

**ТӘРҖЕМӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **тәрҗемә итү**. *Клара ханым, сезнең якта татарчага тәрҗемә кылучы тылмачлар бармы?* И.Юзеев. *Дистәләгән әсәрләр чит телләргә тәрҗемә кылына, басылып чыга иде.* С.Ибраһимова

**ТӘРҖЕМӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәрҗемә эшен башкару, тәрҗемә итү. *Ул алар белән нык аралашып, «тел-лөгать алмашып» яшәде, рухи тормышлары турында һәрдаим язып килде, атаклы кешеләрен үзенең хезмәтләрендә сурәтләде, аркадаш каләмдәшләренең әсәрләрен, турыдан-туры тәрҗемәләп, татар укучысына җиткерде.* Р.Фәйзуллин. *Рус телендәге газеталардан турыдан-туры тәрҗемәләп бирелгән язмаларның мәгънәсенә төшенү өчен, зур тырышлык куярга туры килә.* С.Әхмәтҗанова

2) Аңлату, шәрехләү. *Кызы, анымоны нечкәртеп тормастан, минем дуамал сорауны, әле ярый, шул әйтелеп бетмәгән килеш, гадәттәгечә пышылдап кына әнисенә «тәрҗемәләп» бирде.* Ф.Хөсни

**Тәрҗемәләп бетерү** Барысын да тәрҗемәләү; тәрҗемәләүне төгәлләү. *Бер әсәрне тәрҗемәләп бетерүгә икенчесенә тотына иде.* Кызыл таң

**Тәрҗемәләп бирү** Кем өчендер тәрҗемәләү. *Әмма өлкәне тагын тиз генә арага кысылды, аның һаман да мине каушатасы килә иде шикелле: – Инде соңгы җөмләләрне укып, тәрҗемәләп бирегез, – диде ул.* Й.Хәлиуллин

**Тәрҗемәләп карау** Тәрҗемә итәргә тырышу; тәрҗемә итү омтылышы ясау. *И заманалар, татарга да тылмач кирәк хәзер. Тәрҗемәләп карыйк.* И.Юзеев

**Тәрҗемәләп тору** Сөйләү моментында тәрҗемәләү; әледән-әле тәрҗемәләү. *Без сөйләшкәнне тәрҗемәләп торыр өчен кирәк бит ул.* Мәйдан

**Тәрҗемәләп чыгу** Барысын да башыннан ахырына кадәр тәрҗемәләү. *Кыска гына вакыт эчендә «Калевала»ның бернечә табагын тәрҗемәләп чыктым.* М.Шабаев

**Тәрҗемәли башлау** Тәрҗемәләргә керешү. *Чит телләрдән дә турыдан-туры тәрҗемәли башлау алдында торабыз.* Г.Ахунҗанов. *Кытай галиме Сюэ Цзунчжэнның «Түрк тарихы»н тәрҗемәли башладым.* Т.Әйди

**ТӘРҖЕМӘЛЕ** *с.* 1) Тәрҗемәсе булган, тәрҗемә ителгән; бер телдән икенче телгә күчерелгән. *Кешеләр керәчәк, татар телендә тәрҗемәле спектакль караячак – ярамыймыни?* Казан утлары. *Тәрҗемәле текст*

2) Аерым берәмлекләрнең бер телдән башка бер (яки берничә) телгә тәрҗемәләрен бирә торган. *Татар теленең аңлатмалы һәм тәрҗемәле сүзлекләрендә иллегә якын шундый сүз теркәлгән.* Р.Мөхиярова. *Халыклар арасында дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре ике телле тәрҗемәле сүзлекләрнең төзелүенә этәргеч булып тора.* Фән һәм тел

**ТӘРҖЕМӘЧЕ** *и.* Тәрҗемә эше белән шөгыльләнүче белгеч; тәрҗемә итүче; тәрҗеман, мөтәрҗим, тылмач. *Ни кызганыч, тәрҗемәче даһи Толстойның бөтен әсәргә тональлек һәм юнәлеш биргән табышын сызган да ташлаган.* А.Тимергалин. *Ә мин мәктәпне бетергәч тәрҗемәче булам.* А.Әхмәтгалиева

**ТӘРҖЕМӘЧЕЛЕК** *и.* Тәрҗемә итү теориясе һәм гамәле; тәрҗемәче һөнәре һәм эше. *Сафуан Әлибаев иҗатының тагын бер үзенчәлекле ягын әйтеп китәсе килә. Ул – тәрҗемәчелек.* Р.Миңнуллин. *Тәрҗемәчелекне, язу эшен шулкадәр оста вә пөхтә башкара иде ул, хәтта аның бу сәләте үз башына бер бәла булды ---.* З.Мурсиев

**ТӘРИКӘ** *и. гар. иск.* Үлгән кешедән калган мал; мирас. *Янә бер ай микъдарыннан соң, Гәрәй илүенә бәне алдылар, югарыда яд кыйлынган рәвешчә тәрикә малы өләшер өчен.* Батырша. *Әй угыл, шәригатьтә бер мәсьәлә бардыр ки: әгәр бер бай кеше вафат булып, тәрикә малын --- мөкаддәм варисларның берсе үзенең өлешен сатса, җаизмы, түгелме?* К.Насыйри

**ТӘРКИП** *и. гар. иск. кит.* 1) Кисәкләрне кушу, җыйнау, бербөтен ясау эше

2) Шул юл белән барлыкка килгән нәрсә; состав. *Һәрбер төрки телдә «состав» – рус теленең состав сүзе түгел: казакча «курам», үзбәкчә, азәричә, төрекчә «тәркип», иске татар китапларында да «тәркип» [сүзе] булган.* Фән һәм тел

3) Сүзтезмә. *Синтаксис бүлегендә исә иң зур берәмлек – тәркип.* В.Хангилдин. *[Бу әсәрләрдә] Әллә никадәр гарәби вә фарси сүз вә тәркипләр ---, төрки сүзләрнең дә күбесе татар шивәсенчә түгел.* Җ.Вәлиди

4) Төзелеш, структура. *Тәркип вә өслүбе кемчә вә кемгә тәкълид икәнен бер Ходай үзе генә белсен!* Г.Тукай

5) *пед.* Мәдрәсәдә гарәп сүзтезмәсен өйрәтә торган дәреслек, уку китабы; шул дәреслек буенча гарәп синтаксисын тикшерү, анализ ясаудан гыйбарәт дәреснең үзе. *Үземез хәзер дә мәдрәсәдә укып торамыз. Дәресемез «Тәркип»не чыгып барамыз.* Г.Тукай. *96 нчы елның башындарак тәркипкә төшеп, май башларында [мәдрәсәдән] авылга кайттым.* М.Гафури

**ТӘРКИ́П ИТҮ** *ф. иск.* Өлешләрдән, кисәкләрдән төзү, оештыру, бербөтен ясау. *Егет рус җөмләләрен ялгыш тәркип иткән.* Ф.Әмирхан. *--- халыкның электән ияләшкән вә зәвыкланган бер форма я өслүб илә тәркип итеп, аны күптәннән өйрәнгән көенә биетүен --- [күрәбез].* Җ.Вәлиди

**ТӘРМӘЧ** *и. диал.* 1) Җимешләре укмашып үскәнгә, чук-чук булып асы-

лынып торган сабакчык; тәлгәш. *Балан тәрмәче*

2) Шешә, торба ише әйберләрнең эчен чистарту өчен кулланыла торган, кыллары төрле якка тырпайган әсбап

**ТӘРМӘЧЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Тәрмәчләргә укмашу, тәлгәш барлыкка китерү; тәлгәшләнү

2) Әйләнәсе буйлап төрле якка тырпаеп тора башлау

**ТӘРМӘЧЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Тәрмәчкә җыю

2) Әйләнәсе буйлап төрле якка тырпайту. *Керпе, йомарланып, энәләрен тәрмәчләде*

**ТӘРСИМ** *и. гар. иск. кит.* Рәсем ясау, сурәт төшерү эше. --- *музыка, тәрсим, әдәбият – болар халыкның рухы, болар һәр халыкның үзенә, тик үзенә махсус.* Г.Ибраһимов

**ТӘРСИ́М ИТҮ** *ф. иск.* 1) Рәсем ясау, сурәт төшерү, рәсемләү. *Зәңгәр күзкәйләрен җанлы итеп --- Ничек тәрсим итим мин аны?! Иркә җир кызларын буяу белән Җанлы итеп буяп буламы?* Һ.Такташ

2) Берәр нәрсәне, күренешне, эшне һ.б. сурәтләү, аңлату, тасвирлап бирү. *Мондый олуг темалар, хосусан, бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән --- укучының күз алдына тәрсим итәргә тиештер.* Ф.Әмирхан

**ТӘРСИ́М КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәрсим итү**. *Өмид юк түгел әле: бара торгач, үз арамыздан маһир рәссамнар чыгып, Шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кыйлып чыгарырлар.* Г.Тукай

**ТӘРТӘ** *и.* Ат яки башка хайванны җигү өчен, бер очы арбаның алгы күчәренә яки чана табанының алгы ягына беркетелә торган ике колганың берсе; арыш. *Бозауны арбага салды, сыерны ат белән янәшә тәртә башына бәйләде.* М.Кәрим. *Өй каршындагы лапастан өскә күтәртеп куелган берничә пар тәртә башлары күренә.* М.Хәсәнов ◊ **Тәртә арасына кертү** 1) Атны җигәргә күнектерү, йөк тарту хезмәтенә әзерләү. *Кысрыклап кына атны тәртә арасына кертеп була.* Ф.Дәүләтбаев; 2) Кемне дә булса берәр эшкә тарту, нинди дә булса эш белән шөгыльләнергә мәҗбүр итү. --- *тормыш көтә башлаган егет 20 яшьтә үк үзенә дип бура бурый: нишләсен, тормыш яшьли тәртә арасына кертә шул аны.* Шәһри Казан; 3) Кемне дә булса билгеле кагыйдәләргә, тәртипкә өйрәтү. *Армия егетләрне бераз басты, тәртә арасына кертте, ташып барган көчләрен йөгәнләде.* К.Кара. *Безнең арада да төрле хәлләр булгалагандыр, әмма әнкәй, һәрнәрсәне үз вакытында хәл итеп, безне тәртә арасына кертеп килде.* Ватаным Татарстан. **Тәртә арасына керү** 1) Эш яшенә җитү, мөстәкыйль эшли алырлык булу. *Әтисе дә эш кушкан саен: «Зур егет инде син, тәртә арасына керергә күптән вакыт», – дигән була.* Г.Фарсыева; 2) Эшкә алыну, эшли башлау. *Өстәвенә егәре тормыш арбасын тартырлык булып ныгыганчы ук тәртә арасына керде*... М.Хуҗин; 3) Тәртипкә, дисциплинага өйрәнү. **Тәртә арасында тоту** Куелган таләпләрнең, шартларның үтәлешен тәэмин итү. *Җиһанны үзидарә режимында тоту өчен, Планетар Зур пространствоны региональ каршылыклы кисәкләргә бүлгәләү мәслихәт --- «бүлгәлә һәм идарә ит» мәсләген куллану халыкларны тәртә арасында тотуны җиңеләйтә.* Р.Сафин. **Тәртә аша сикерү** Куелган чикләрне, кабул ителгән тәртипне бозу, тиешле кагыйдәләрне сакламау. *Абруйсызланып тәртә аша сикерүчеләрнең колакларын да борабыз.* Г.Минский. **Тәртә башы белән орыну** 1) Саксыз йөреп нәрсәгә дә булса бәрелү, аударып җимерү, вату. *Кече якта нәрсәнеңдер дөбердәп идәнгә ауганы ишетелде: әллә кызган шәпкә тәртә башы белән орынып, әллә юри әйбер атып бәреп, Наилә үзенчә бер «кыямәт» кубарып алды.* Ф.Хөсни; 2) Кемгә дә булса сүз тидерү, аны тәнкыйтьләү. **Тәртә башы чәйнәү** Берәр нәрсә өчен бәхәсләшү, карышу, талашу. *Хөснулла компаниясе тәртә башы чәйнәп карады да чиләндерә алмады. Дүдәк күле һәм Тубылгы аланыннан ике йөз кырык дисәтинә җирне [җәмәгать] безнең чутка кисәргә [әйтте].* Ш.Камал. **Тәртә буе** 1) Халыкта борынгы озынлык үлчәме (2–3 м чамасы). *Урысның төп биләмәләренә барып кергәч, тәртә буе --- гына калкына алган нәп-нәзек наратларны, кәкре, гарип каеннарны күргәч, күңел тарихка борылып кайта.* И.Гыйләҗев; 2) Кирәгеннән күпкә озын. *Башкисәрнең тәртә буе кылычын баш очына күтәрүе булган, хатыннарның берсе: «Балам!» – дип кычкырып, һуштан язып егылган.* Г.Гыйльманов. *Дүрт елда яңадан тәртә буе үсә икән.* Мөгамбәр Галиев. **Тәртәгә аркылы килү** Каршылыклар, комачаулыклар, тоткарлыклар килеп чыгу. *Ул көнне ничектер безнең тәртәгә гел аркылы гына килеп торды. Разведчиклар да ниндидер ачыгавызлар эләккән иде*... Казан утлары. **Тәртәгә җигелү** Нәрсә дә булса эшләү, нинди дә булса эшкә, җитәкчелек итүгә алыну. *Зәмзәмия һәм Габдрахман Гайфетдиновлар 60 ел тормыш арбасын бер тәртәгә җигелеп тарталар икән.* Татарстан яшьләре. **Тәртәгә кертү** Дөрес юлга күндерү, төзәтү; гомумән билгеле таләпләргә буйсындыру, кагыйдәләр белән чикләү. *Иҗат иректә булырга тиеш, аны тәртәгә кертү файдасыз!* З.Низаметдинов. *Ай-һай, закон дип кенә «урман – гомуми байлык» дип пырдымсыз яшәргә өйрәнгән халыкны тәртәгә кертеп булырмы икән?* Ватаным Татарстан. **Тәртәгә керү** *к.* **тәртә арасына керү**. *Әгәр син тәртипкә буйсынасың икән – ул [әткәй] булыша, әгәр тәртәгә кермисең икән – якын барма.* Ватаным Татарстан. **Тәртәгә тибү** Холыксызлану, дуамаллану, характер күрсәтү; усаллану, киреләнү. *Тәртәгә тибеп маташсаң, телеңне тешләтергә дә күп сорап тормый*... Ә.Дусайлы. *– Юк, – диде чал чәчле судья хатын, – сеңелем, син тәртәгә типмә, балага ата кирәк, бер азынып да бер тынар.* Идел. **Тәртәдән чыгу** 1) Начар юлдан китү, юлдан язу, бозылу. *Тәртип бозулар, яшьләрнең тәртәдән чыгып йөрүләре дәүләт югарылыгында тыелса, моның нинди начарлыгы булыр иде икән?!* Кәеф ничек?; 2) Артыгын әйтеп ташлау, артыгын сөйләү. *Чит*

*илдән әллә ниткән ит, икмәк кертканче, үзебезнең продукцияне саттырыр идем, авылда хезмәт итүчеләр --- санаторий-курортларда ял итәрләр иде. Тәртәдән чыга башладым бугай. Төп фикеремне аңлагансыздыр: телевизор яисә Мактау грамотасы биргәнче, механизатор Гафиятуллага, терлекче Мәмдухага лаеклы тормыш кирәк.* Татарстан яшьләре. **Тәртә җимерү** *к.* **тәртә сындыру**. *Гомумән, Гасиман Ширгазин, тәртә җимерергә яратучанрак кеше булса да, әлеге фильмын җиргә төшебрәк, гадирәк һәм нәфисрәк итеп башкарып чыккан, миңа калса.* Татарстан яшьләре. **Тәртә каеру** 1) Тәртәне чанага беркетү. *Сугыш еллары, авылда тәртә каерырлык та ир-ат юк.* Р.Вәлиев; 2) *к.* **тәртәне (кирегә) бору**. *Кайтып җитмәгән, ә инде тәртә каеру ягында.* С.Шәрипов. **Тәртәне (кирегә) бору** 1) Килгән якка кире юнәлү, килгән якка кире кайта башлау. *Гел рәхәт кенә эзләп чаптыгыз шул: башта илне ташлап киткәнсез, анда эшләр кыза башлагач, монда таба тәртәне бордыгыз.* Татарстан яшьләре; 2) Алдагының киресен сөйләү, бөтенләй башкача фикер яки эш йөртә башлау, элекке уеннан, сүзеннән, ниятеннән кире кайту. *Хосусән кадетларның шулай тәртә борулары, крестьян законы каралганда, ап-ачык мәгълүм булды.* Г.Исхакый. *– Бу бик катлаулы эш, без ике кандидатураны карадык инде, ризалар да бар, каршы төшүчеләр дә... – дип, тәртәне кирегә бора башлады кабинет хуҗасы.* Р.Мирхәйдәров. **Тәртәне кире(гә) каеру** *к.* **тәртәне (кирегә) бору**. *Тәртәне кирегә каерма, улым, сындырырсың.* Р.Вәлиев. **Тәртә пычрату** Эшнең рәтен җибәрү, эшне бозу. **Тәртәсе җитү** Нәрсәнең дә булса серенә төшенә алу, аңлый алу. *– Пушшай анда мине Иманкол хаҗи: «Туң надан!» – дип әрләсен. Аңа кая әле миңа җитү! --- Анысына инде берсенең дә тәртәсе җитми.* К.Нәҗми. **Тәртәсе зиректән** *к.* **тәртәсе кыска**. **Тәртәсе кыска** Тиз кызып китә, сүз күтәрми торган, тиз ачуланып, дуамалланып китүчән. *Өлкәннәр инде теш кысып булса да түзәргә өйрәнгән, ә менә яшьләрнең тәртәсе кыска. Ризасызлыгын алар төрле протест ярдәмендә белдерә.* Туган як. **Тәртәсе тиз сынучан** *к.* **тәртәсе кыска**. **Тәртә сындыру** Башкаларга каршы барып, киреләнеп, дуамалланып эшне бозу. *Дулап, тәртә сындырырга ашыкма, Харрас.* Җ.Дәрзаман. *Дөрес, гадел әйтелмәгән, үзенә ябышмаслык сүзләрдән кызып китеп тәртә сындыру гадәте дә юк түгел Рафиянең.* Р.Рахман. **Тәртә сыну** Берни эшли, беркая бара алмас хәлгә төшү. *Өндәмә, Минһаҗетдин, өндәмә, яме... Синең үзеңнең дә ул турыда тәртәң сынган.* К.Тинчурин. **Тәртә төртсәң үсеп китәрлек** Туфрагы бик уңдырышлы. *«Безнең якта җиргә тәртә төртеп куйсаң да үсеп китә», – диде украин егете.* Г.Әпсәләмов. **Тәртә түбәнгә карау** Эшнең рәте китү, кирегә тәгәрәү. *Гыйлаҗны әвен бригадиры итеп билгеләделәр: заманында председатель дә, агротехник та булган кешегә бу инде, ни генә әйтмә, тәртәләрнең түбән карый баруы иде.* Р.Төхфәтуллин

**ТӘРТӘ́ БАВЫ** *и.* Тәгәрмәч күчәренең очыннан тәртә башына тарттырып куела торган бау; тәҗе. *Авыл агайлары әйтмешли, тәртә бавы нәкъ тауның очына менеп җиткәндә өзелә язды.* А.Хәсәнов

**ТӘРТӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Атны арба-чанага тәртәләр ярдәмендә җигү. *Мәсәлән, тәртәләп җигелгән сугыш арбалары Месопотамиядә, Мисырда, Микена чоры Грециясендә, Кавказ артында, Төньяк Европада, Алтайда, Монголиядә очрый икән.* Н.Фәттах

2) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса кагыйдәләргә буйсындыру, тәртипкә салу. *Тәртәләп нәфесең атын, баш өстенә бөк[тең] дага.* Ш.Бабич

**ТӘРТӘЛЕ** *с.* 1) Билгеле сандагы яки сыйфаттагы тәртәсе булган, тәртәләп җигелгән. *Әйбәт чабышкы син, мәгәр бәһаңне белмиләр, кыска тәртәле арба-чаналарга җигеп җәфалыйлар икән шул сине.* В.Имамов. *Халил зыбанына төренгән килеш --- бер тәртәле, пар ат җигә торган чанада, ике тимер бучка керосинга терәлеп утырган.* В.Ильясов

2) Тоткалы, саплы. *Арттагы рәтләрдә мәңгелек аспирантка охшаган чал чәчле, кайчандыр тәбегә кыстырып алынгандай чыраена калын тәртәле күзлек элгән бер егет кычкырып җырлап җибәрде.* Идел

3) *күч. сөйл. к.* **арбалы** (*3 мәгъ.*). *Ләкин тәртәле Ришат барысын да боза: кызга бәрелә, һәм аның сумкасы ертыламы шунда (киноларның хисле җирендә әфлисуннар тәгәрәшә бит әле)... монда да шул ук хәл! Уенчыклар --- чәчелә!* Л.Мәрданова

**ТӘРТӘЛЕК** *с.* **1.** Тәртә өчен ярый торган. *Тәртәлек каен*

**2.** *и. мәгъ.* Тәртәгә яраклы колга. *Балта күтәреп, тәртәлек эзләргә чыктым.* Г.Ахунов. *Сбруйлар көйләп йөрүче Вәҗетдин бабай мине сүгепме сүгә: «Тәртәң сынды бит, мин каян тагын тәртәлек табыйм?» – ди.* Ватаным Татарстан

**ТӘРТЕК** *с. диал.* Өзеп алынган, кисеп кыскартылган. *Өзек белән тәртек икесе бер.* Мәкаль

**ТӘРТЕШКӘ** *и. диал.* 1) Ашлык сукканда, ашлыкны бер урыннан икенче урынга күчерү, өю яки тарату, түтәл ясаганда, туфрак тигезләү өчен, уртасына сап утыртылган кыска тактадан гыйбарәт эш коралы; тарткы. *Кара урман, кара урман артыннан --- шаркылдык, шаркылдык артыннан селкенчәк, селкенчәк артыннан тәртешкә, тәртешкә артыннан тырма.* Әкият

2) Мичтән күмер тарту өчен «Г» хәрефе формасындагы әйбер; кисәү агачы

3) Ике торбаны почмак ясап тоташтыра торган өстәмә деталь

4) *күч. шелт.* Килешсез сузылган кул-аяк. *Тәртешкәләреңне җыя төш*

**ТӘРТИБЕНДӘ** *бәйл.* 1) Нәрсәгәдер нигезләнеп, нәрсәдер нигезендә; буенча, күрә. *Бар эш тә закон тәртибендә алып барыла.* К.Кара

2) Буларак, рәвешендә; өчен. *Малай чаклардагы кебек, сынау тәртибендә кулымны кисәк кенә күтәргән идем, Ишембаев күзләрен ирексездән йомды һәм башын читкәрәк алды.* А.Тимергалин

**ТӘРТИП** *и. гар.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса урнашуында төгәл эзлеклелек. *Вәлиулла күзлеген киде, алфавит тәр-*

*тибендә тезелгән исемлекне ашыкмыйча, хәтеренә сеңдерергә тырышып кына укый башлады.* Р.Низами. *Безнең полкны дивизия командиры үзе җитәкли һәм ул төркемнең авангардында оча, ә эскадрильябыз тәртип буенча санаганда – икенче.* Ф.Хуҗин

2) Әйбер, җиһаз, әсбапларның куелышында, торышында уңайлылык, җыйнаклык. *Һәрнәрсә нәкъ тиешенчә, нәкъ кирәк урынына куелган, кухнядагы тәртипкә Фәләхнең исләре китә торган иде, ә бит йорт-җирне шулай гөл итеп тору җиңел эш түгел!* В.Нуруллин

3) Тиешле дәрәҗәдә, рәвештә көйләнгәнлек, оешканлык. *Инде менә өченче кат тәхет яулагач, Казанда тәртип урнашкач, Сафа Гәрәй хан Зөннарны «мирза» дип атый башлады.* Р.Батулла. *Димәк, өендә тәртип: киемсалым юылган, җәмәгате юк-барга чәүчәләкләнеп, чокчып торучылардан түгел, туклану мәсьәләсе дә үз югарылыгында*. Р.Кәрами

4) Иҗтимагый төзелешнең, идарә итүнең билгеле бер системасы, дәүләт төзелеше. *Патшаны бәреп төшергәннән соң, илдә яңа тәртип керә башлагач та, Хәсәнбайны шушы горурлыгыннан мәхрүм итәргә тырышып карарчылар җитәрлек булды*. М.Кәбиров

5) Эш барышында яки тормышта урнашкан, кабул ителгән билгеле күрсәтмәләр, боерыклар үтәлешендә тайпылышсызлык, көйләнгәнлек; кагыйдә, законнар җыелмасы. *Үзебезгә кирәкле китаплар исемлеген җибәрәбез, йөзләгән-меңләгән китаплар алдырабыз һәм үзебез дә алар сораган китапларны җибәреп торабыз. Берберебезгә акча түләмибез, тәртип шулай.* Р.Вәлиев. *Бюродагы эчке тәртип буенча, гид программадан читкә тайпылмаска, ягъни клиентлар белән артык үз итеп аралашмаска, аларга үз фикерен такмаска, тормыш-яшәүләре белән кызыксынып, гайрәтләрен чигермәскә тиеш иде.* Н.Гыйматдинова

6) Җәмгыятьтә, коллективта барлык кешеләр өчен үтәлүе мәҗбүри булган кагыйдәләргә буйсынганлык, үз-үзеңне тотыш; дисциплина. *Ә эше күп: класста тәртип йомшарып китсә дә, берәр төрле ЧП килеп чыкса да, --- – барысы өчен иң элек комсорг җавап бирә.* В.Нуруллин. *Кечеләр олыларны хөрмәт итү, итагать, тәртип, хөрмәтле кешегә буйсыну тормыш канунында, төбендә ятарга тиеш!* Г.Каюмов

7) Берәр нәрсәнең үтәлешендә билгеле бер ысул, якын килү, куелган таләпләр. *Син әйләнешкә керткән салым тәртибе турында ишетеп, минем король моңа гел мөкиббән.* В.Имамов

8) Берәр эшне үтәү, башкару өчен гомуми кабул ителгән кагыйдәләр, шартлар. *Әмма акланырлыгы да бар: уен тәртибе шундый булуны таләп итә иде.* Ф.Яхин. *Документлаштыру тәртибе белән танышканнан соң, Роберт Хисамович үзенең фатихасын бирде*. К.Кара

9) Билгеле бер рәвештәге төзелеш, торыш. *Юк, болар гына түгел, күктә көнбатышка таба төркем-төркем очып үткән һәм бомбаларын ташлаганнан соң тәртип белән тезелешеп кайткан кызыл йолдызлы самолётларны да бөтен халык күрә бит*. А.Тимергалин

10) Күнегелгән, электән килгән гадәт, традиция. *Никах, туй, кодалашу кебек йолалар үз тәртибе белән гамәлгә ашырыла.* Р.Әмирхан. *Үзебезнең тәртип белән өстәлләрен дә көйләдем*. Г.Галиева

11) Нәрсәнең дә булса җае, рәте, аерым нечкәлекләре. *Әби үзе 10 бала алып кайткан, гыйлемен балаларына бирергә тырышкан, намаз тәртибен, Коръән укырга өйрәткән*. Н.Садыйкова. *Яркәевнең немецлардан калган алачыктан файдалануын, тимер белән эшләү тәртибен белеп алган майор, солдатны тимерче һәм бакырчы итеп билгеләде.* Ютазы таңы

12) Җай, чират, нәүбәт. *Туктагыз, мин тәртибе белән сөйлим...* А.Тимергалин. *Бар да үз тәртибе белән бара, инде менә «Төрлеләр»гә дә килеп җиттеләр.* Н.Көбәш

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* Тиешле дәрәҗәгә китерелгән, көйләнгән, җайланган хәлдә. *Запчастьлар белән дә тәртип...* Н.Хәсәнов

**ТӘРТИ́П ИТҮ** *ф. кит.* 1) Аерым өлешләрдән, нәрсәләрдән бер бөтен оештыру, төзү. *Иң элек белгәннәрдән мәгълүмат алына, кабер ташлары, күп төрле чыганаклар өйрәнелә, аерым шәхесләр тормышы, шәҗәрәләр тикшерелә, шулардан кабилә-ырулар тарихы төзелә, соңыннан, барысын бергә җыйгач кына, халыкның гомуми тарихы тәртип ителә.* Р.Фәхретдин

2) Материалларны, әйберләрне билгеле бер эзлеклелектә җыю, тиешенчә урнаштыру; тәртипләү, тәртипкә салу. *Сөем тутай белән ахирәтләр бу гомер эчендә атасының көтебханәсен тәртип итеп, алып кайткан кулъязмаларны коры урынга тезеп, һәр китапның кайсы бүлмәдә, кайсы теземдә, кайсы киштәдә, кайсы урында икәнен бик тиз табар өчен, аерым җәдвәл төзеп куйдылар.* Р.Батулла

3) Аерым кешеләрне сайлап алып, бер төркем, коллектив оештыру, төзү. *Әнвәр паша янына Кәбир Бәкер генә түгел, Әфганстаннан, Бохарадан, Ташкенттан вә Бакудан, тагын әллә кайлардан киләләр, алар Әнвәр паша бөтенмөселман гаскәре тәртип итеп, газават юлына басар, дип өметләнә иде.* Р.Батулла

**ТӘРТИПЛӘП** *рәв.* 1) Эзлекле рәвештә. *Тәртипләп сөйләргә рөхсәт итегез, зинһар.* Р.Батулла

2) Җентекләп, тәфсилләп, барлык нечкәлекләрен дә исәпкә алып. *Умарталык өчен борчылган юк, барысын да үзе тәртипләп алып бара, ышанычлы егет.* Г.Галимуллина

**ТӘРТИПЛӘ́Ү** *ф.* 1) Билгеле бер тәртип булдыру, тәртипкә салу; эзлеклелек булдыру. *Максаты – архив документлары турында бер дәфтәр булдырып, шуларны тәртипләп яздыру була.* Р.Фәхретдин

2) Тәртипле итү, җыйнак, пөхтә хәлгә китерү. *Ханым вә туташлар тезелешеп чәчәкләр китерәләр, кабер өстенә тәртипләп тезәләр, кабернең туфрагы күренми, ул хәзер кабер түгел, чәчәк өеме булып әверелә.* Ә.Хәсәни

**Тәртипләп бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы тәртипләү. *Бу авылның феноменаль булган мәхәллә структурасы хакында, авылны тәртипләп барган Иҗтимагый киңәшмәсе*

*турында тапшыру төшерделәр.* Р.Җәмдихан

**Тәртипләп бетерү** Тулысынча тәртипләү. *Тимеркәй өстәлне тәртипләп бетерә.* Г.Ибраһимов. *Әлегә эш программаларын тәртипләп бетерәсем бар, Резеда.* Г.Җәлилова

**Тәртипләп бирү** Кем өчендер тәртипләү

**Тәртипләп карау** Тәртипләргә омтылу

**Тәртипләп кую** Тәртипле хәлгә китереп калдыру. *Барысын да тәртипләп куйгач, Нәфисә әби, идән уртасына басып, дөньяның дүрт тарафын да барлаган шикелле, өй эчен күздән кичерде.* М.Галиев. *Ярый әле көздән үк бүрәнәләрне тәртипләп куйганнар.* Р.Гаязетдин

**Тәртипләп тору** Һәрвакыт, гел тәртипләү. *Шулай булса да мерәслеләр чишмәне карый, һәрдаим аның тирәсен чистартып, тәртипләп тора.* Ватаным Татарстан. *Авыл уртасына менә дигән күпер салдык, колхоз вакытында да каралмаган юлларыбызны карап, тәртипләп торабыз.* Татарстан яшьләре

**Тәртипләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барысын да бер-бер артлы тәртипләү. *Бар материалларыгызны системага салып тәртипләп чыгу – күп көч сорый торган бик вак эш инде ул.* Г.Җәлилова. *Тик шулай да бер чуалган тормыш җебенең очын табарга, һәрнәрсәне нульдән диярлек торгызып, тәртипләп чыгарга бу ябык иңнәрнең генә көче җитәрме?* Ватаным Татарстан

**Тәртипли башлау** Тәртипләргә тотыну

**Тәртипли төшү** Тагы да бераз тәртипләү

**ТӘРТИПЛЕ** *с.* **1.** 1) Төгәл бер тәртипкә, төзелешкә ия булган. *Агглютинатив телләрдә сүзформа төзелеше гади, ачык һәм тәртипле.* Ф.Сафиуллина. *Пыяла ясау процессының ахырында, аеруча пыяланы суыту стадиясендә, сыек эретмәдә тәртипсез йөзеп йөргән матдә кисәкчекләре тәртипле кристаллик структурага урнаша.* Төзү материаллары

2) Ватык булмаган, төзек, куллануга әзер булган. *Мин коралларны тикшереп чыгам: бөтенесе дә тәртипле.* И.Гази

3) Үз-үзен тотышында җәмгыятьтә кабул ителгән тиешле кагыйдәләргә буйсынып яши торган; дисциплиналы. *Бергә эшләгән иптәшләре – уңай холыклы кешеләр, белемле, тәртипле халык.* К.Кара. *Әгәр дә берәрсе, ул шук малай, тәртип бозарга ярата, дисә – ышанмагыз. Миннән дә тәртипле укучы юк ул.* И.Диндаров

4) Законнарны бозмаган, законга буйсынып яши торган. *Тилләхаҗиев һәрчак тылны тәэмин итү хакында уйланган, теләсә нәрсә кылырга мөмкин көннәрнең үтәсен белгән, менә шул чакта инде аңа бар яктан килгән, бар яктан тәртипле район кирәк булачак.* Р.Мирхәйдәров. *Күзәтүләрдән күренгәнчә, алар [хөкем ителгән ун кеше] тәртипле тормыш алып баралар, туры юлга басарга омтылалар.* Л.Низамиева

5) Төпле, төгәл, эзлеклелек саклаган. *Мин, бу соравыңа тәртипле һәм нигезле җавап бирергә кирәк, дип саныйм.* Р.Вәлиев

6) Җыйнак, пөхтә, чиста булган. *Галиянең йорты авылның иң чиста, иң тәртипле йорты дип танылды.* Татарстан яшьләре. *Аның җитез атлавына, пөхтә һәм тәртипле ишегалдына, янбакчада үскән җимеш куакларына карап, йорт хуҗасының 90 яшьне тутыруына ышанасы да килми.* Шәһри Казан

7) Матур итеп зәвык белән корылган, эшләнгән, күзгә күркәм күренгән. *Яшь киленнең тәртипле, матур, мул табыны әзер иде.* Ә.Еники

8) Каралган, тәрбияләнгән, тәрбия күргән. *Югыйсә бакчабыз элек бик матур, бик тәртипле иде.* Ә.Еники

9) Сәламәтлеккә зыян китерә торган зарарлы гадәтләрдән азат булган. *Зарарлы гадәтләрдән баш тарту омтылышы, тәртипле тормыш рәвеше сәламәтлегегезне ныгытачак.* Шәһри Казан

10) Яхшы тәрбия алган, яхшы тәрбияләнгән, тәрбияле. *Яхур патша яшь чакта бик тәртипле, итагатьле бер бала булып үскән икән.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Даими рәвештә, эзлекле, системалы. *[Журнал] Дәвамлы, тәртипле чыгып торуы белән дә абруй казанды, күп таралды, күп укылды...* Л.Хәмидуллин. *Налогларны тәртипле түләп бару*

2) Билгеле бер план, тәртип белән, оешкан төстә. *Эшләре тәртипле барсын өчен, алар алдан ниятләп, --- киңәшеп, планлаштырып куялар.* Ф.Яхин

3) Билгеле бер эзлеклелек саклап, эзлекле рәвештә. *Ни өчен көн, төн тәртипле алмашынып тора?* Ф.Әмирхан. *Силлабо-тоник система басымсыз һәм басымлы иҗекләрнең тәртипле чиратлашуына корыла.* Әдәбият белеме

4) Күркәм, матур, әйбәт, югары бәягә лаек. *Табын янында Шәрәфи була икән, көт тә тор: мәҗлес матур, күңелле һәм тәртипле узачак.* Р.Батулла

**ТӘРТИПЛЕЛӘНҮ** *ф.* Тәртиплегә әйләнү, тәртипле булып китү. *Әллә яшь инспекторларның рейдка күп чыгуыннан биредәге җәяүлеләр шулай тәртипләнгәннәр: юл билгеләрен санламаучылар әллә ни күп булмады.* Сабантуй

**Тәртипләнә бару** Акрынлап, азазлап тәртиплегә әйләнү

**Тәртипләнә башлау** Тәртиплегә әйләнүе сизелү

**Тәртипләнә төшү** Бераз тәртипләнү

**Тәртипләнеп бетү** Тәмам, тулысынча тәртипләнү. *Бөтенләй яхшырып, тәртипләнеп бетәрмен дә сәхнәдән китәрмен дип уйлыйм.* Тамаша

**Тәртипләнеп килү** Акрынлап, азазлап тәртипләнгәне күренү

**Тәртипләнеп китү** Бераз, бернигадәр тәртипләнү. *Дога өйрәнер, Аллаһ сүзен ишетер, тәртипләнеп китәр иде, диләр.* Н.Әлмиева

**ТӘРТИПЛЕЛЕК** *и.* 1) Билгеле бер тәртипкә буйсынганлык, системалылык, эзлеклелек. *Рифмасыз ирекле шигырь-рифма анафора рәвешендә юл башында гына очрый, иҗекләр дә төрле юлда төрлечә, ләкин үзенә күрә чагыштырмача тәртиплелек бар икән.* Н.Юзиев. *Аерым бер сүзләрнең кулланылышы күбәеп китә, төшенчә билге булудан туктый, тәртиплелек югала.* М.Кәбиров

2) Тәртипле, әдәпле булу сыйфаты. *Һәрберебезнең күңелендә ул [Туфан Габдулла улы Миңнуллин] тәртиплелек, гаделлек һәм теләктәшлек үрнәге булып сакланачак.* Сәхнә

**ТӘРТИПЛЕ́-ТӘРТИПСЕЗ** *рәв.* Билгеле бер тәртип сакланмыйча, теләсә ничек. *Каерылган ишекле вагоннар, тәртипле-тәртипсез янып яткан һәм инде күбесе көлгә әверелгән учак урыннары, һәр җирдәге җансызлык аңа күп нәрсәләр хакында сөйләргә мөмкин.* Ф.Яхин

**ТӘРТИПНАМӘ** *и. гар.-фар. иск.* Тәртип кагыйдәләре; устав; режим. --- *«Приказчикларыңызны җәбер итеп кысып тот, хезмәтләрен 18 сәгатьтән киметмә, тамакларына яхшы итеп бирмә – шәригать кушмый», – дия, мәшһүр хәзрәтләремезнең тәртипнамә язып йөрүләре.* Г.Тукай

**ТӘРТИП-НИЗАМ** *җый. и. гар.-гар.* 1) Тиешле дәрәҗәдәге оешканлык, ныклы кагыйдәләргә буйсынганлык; дисциплина. *Мәҗлес гауга вә кычкырышсыз, тәртип-низам илә булды.* К.Мотыйгый. *Бүгенге урыс матбугаты Октябрь фетнәсенә кадәрге Русия тормышын бик мактап сурәтләргә ярата, янәсе, патша вакытында халык мул яшәгән, тәртип-низам булган.* Татарстан яшьләре

2) Эш итү кагыйдәсе, юлы, ысулы. *Шундый затлы, мәһабәт бинаны [Кол-шәриф мәчетен] төзеп тапшыргач, тәртип-низамы да кешечә – уңайлы, итагатьле, татарча кунакчыл булырга тиеш иде югыйсә.* Татарстан яшьләре

3) Билгеле бер нәүбәт, эзлеклелек. *Аннан соң Әбүгалисина сүз энҗеләрен тәртип-низам җебенә тезеп: – И җаным әфәндем, мин ихтыярым беләнме киттем? – [диде].* К.Насыйри

**ТӘРТИ́П САНЫ** *и. лингв.* Предметның сан буенча тәртибен белдерә торган төркемчәсе. *Тәртип саны күбрәк предметны ачыклый һәм җөмләдә аергыч булып килә.* Ф.Хисамова

**ТӘРТИПСЕЗ** *с.* **1.** 1) Төгәл бер тәртипкә, төзелешкә ия булмаган. *Бу дулкыннар тәртипсез хаотик хәрәкәттә була.* Татарстан яшьләре

2) Эзлеклелек булмаган, буталчык, чуалчык. *Куркыныч һәм тәртипсез төшләр, көндез фикерләп йөргән нәрсәләр белән йокыда саташулар Рәсүлуллаһ хәдисендә «шайтан уйнавы» дип тәгъбир ителә.* Р.Фәхреддин

3) Тәртип сакланмаган, әйберләр үз урынына урнашмаган, таркау, җыйнаксыз. *Әйберләр, җиһазлар шулкадәр тәртипсез ки, күрәсең, аларга айлар, еллар буе кул тимәгән.* Р.Батулла. *Өстәл һәм рояль өсләрендә кочагы-кочагы белән нота кәгазьләре, аларның байтагы тәртипсез рәвештә тәрәзә төпләрендә дә чәчелеп ята.* Р.Низамиев

4) Кабул ителгән кагыйдәләргә буйсынмый торган, дисциплинасыз; тәрбиясез. *– Нәрсә эшләп йөрисең син монда, тәртипсез кызый?! – дип кычкырды куркуы ачуга алышынган тавышы белән Вестон ханым.* А.Азимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле бер оешканлыкны сакламыйча, таркау рәвештә, теләсә ничек. *Әле анда, әле монда тәртипсез таралып утырган бу кыйшык өйләр тирәсендә каралты-кура, киртә-койма ише хуҗалык корылмалары күренми генә түгел, кайсыберләренең хәтта түбәләре дә юк иде.* М.Галәү. *Пыяла ясау процессының ахырында, аеруча пыяланы суыту стадиясендә, сыек эретмәдә тәртипсез йөзеп йөргән матдә кисәкчекләре тәртипле кристаллик структурага урнаша.* Төзү материаллары

2) Эзлеклелек сакламыйча, буталчык, чуалчык итеп. *[Дуслар] Бер нәрсәдән икенчегә сикереп, аннан тагы кире кайтып, үзләренең башыннан кичкәннәрне тәртипсез сөйләп үттеләр.* Г.Ибраһимов

3) Тәртипкә буйсынмыйча, бердәмлек сакламыйча. *Чәчрәп барып төшкән башлыкларын күреп, калганнар бермәлгә каушап, тукталып калдылар, әмма шундук, кем ятып, кем тезләнеп, тәртипсез атарга керештеләр.* Г.Гыйльманов. *Әмма болар [кошлар сайравы] нindidер тәртипсез шаулашу түгел, табигый бер симфония сыман тоела.* Ф.Яхин

4) Әхлак-әдәп кагыйдәләрен бозып; дисциплинага буйсынмыйча, тәрбиясез рәвештә. *Ул армиядә чакта әниләре үлгән, әтисе башка хатын янына күчеп киткән булганлыктан, егет тәртипсез яшәргә күнегеп килә иде.* Айгизә

5) Тигез генә ятмаган, төрлесе төрле якка карап, шома түгел. *Матур, зифа тәнле, әмма тәртипсез як-якка таралып торган озын кара чәчле егет, уң кулын күкрәгенә куеп, исемен әйтте.* Г.Гыйльманов

**ТӘРТИПСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Тәртипсезгә әйләнү, әдәпсез булып китү

2) Үзен тәртипсез тоту, тәртип бозу. *Тәртипсезләнеп, шәләй-вәләй йөргән бер малай әнә ничек үзгәргән: бөтенләй икенче кешегә – кыяфәтеннән ашкыну һәм ихтыяр көче бөркелеп торган, сокланып туймаслык егеткә әверелгән.* М.Хәсәнов. *Болай тәртипсезләнсәгез, мин бер-берегезне күрми торган итәм.* Г.Гыйльманов

3) Тәртип бетү, җыйнаксызлану; пөхтәлек бетү. *Ниһаять, хатын йорт эшләрен куя: --- һәрбер нәрсә тәртипсезләнә, һәр җирне тузан баса, ирнең дә, балаларның да ашау-эчүләре, киемсалымнары игътибарсыз куела.* Г.Бубый

4) Эзлеклелек югалу, буталчыкка әйләнү. *Тагын нәрсәдер әйтергә теләгән сыман булып, [әни] авызын ачса да, сүзләре тәртипсезләнделәр, өзек-өзек булып, аңлашылмый башладылар.* М.Гафури

**Тәртипсезләнә бару** Торган саен ныграк тәртипсезләнү. *Гомумән халык оятсызлана, комсызлана, тәртипсезләнә бара.* И.Фәйзрахманов

**Тәртипсезләнә башлау** Тәртипсезләнергә тотыну

**Тәртипсезләнә төшү** Тагын да ныграк тәртипсезләнү

**Тәртипсезләнеп алу** Бераз, берара тәртипсезләнү. *Әллә бер шукланып, тәртипсезләнеп алырга инде?* Р.Габделхакова. *Минем уйлавымча, һәрбер бала әзрәк шаярып, тәртипсезләнеп ала инде ул.* Татарстан яшьләре

**Тәртипсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык тәртипсезләнү

**Тәртипсезләнеп йөрү** Төрле урыннарда үзен тәртипсез тоту. *Ата-анасы кая бу баланың, алардан, синең балаңмы бу, синеке булгач, нишләп болай тәртипсезләнеп йөри, дип сорыйк әле.* Р.Вәлиев

**Тәртипсезләнеп килү** Электән, даими рәвештә тәртипсезләнү. *Сорауларга җавап биргән базар җитәкчесе урынбасары десантчыларны гаепләргә теләмәде, ул бары тик «аларның ел*

*саен исереп, тәртипсезләнеп килүе сатучыларга ошамый» дип кенә әйтә алды.* Б.Тимерова

**Тәртипсезләнеп китү** Кинәт тәртипсезлек күрсәтү

**Тәртипсезләнеп тору** Әле, хәзер, күз алдында тәртипсезләнү; әледән-әле тәртипсезләнү

**ТӘРТИПСЕЗЛЕК** *и.* 1) Махсус билгеләнгән тәртибе булмау; хаос. *Ягъни дөнья мифологиясендә киң таралган бик борынгы чор җиһанындагы тәртипсезлек төшенчәсе безнең милли мифологиядә дә билгеле бер чагылыш таба.* Татар халык иҗаты

2) Җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләрне бозу, тәртипсез булу; дисциплинасызлык. *Син эчке тәртип кагыйдәләренә туры килми торган тәртипсезлек эшләгәнсең.* Р.Батулла. *Сәйфи мәктәптәге тәртипсезлекләргә каршы еш кына баш күтәргән, шуңа күрә директор белән тыныша алмаган, ата-аналардан акча җыюга каршы да чыгыш ясаган ул.* З.Хәким

3) Буталчыклык, чуалчыклык, эзлексезлек. *Әллә Әхмәтша хәзрәтнең үзенең укытуында бер кимчелек вә сабак үгрәтүендә бер тәртипсезлек бар микән?* Ф.Кәрими

4) Җыйнаксызлык, пычраклык. *Эчтә төзелештә була торган тәртипсезлек хөкем сөрә иде: стеналар сыланмаган, идән җимерек хәлдә.* М.Маликова. *Юнәлгән вакытында бүлмәдә, кухняда һәм алгы бүлмәдә булган тәртипсезлек күзенә чалынды, әмма җыештырырлык әмәл юк иде.* В.Исламетдин

5) **тәртипсезлекләр** *күпл.* Халык массаларының икътисади, революцион характердагы чуалышлары, кузгалыш, баш күтәрү. *Шаһгали хан Зөя крепостен төзеп анда базар оештыргач, Казанда тәртипсезлекләр күплектән, Казан базары сүнә һәм Зөягә күчә.* Ш.Мәрҗани. *Чәршәмбе тәртипсезлекләр вакытында тоткарланып зинданга ябылганнарны азат итү башланды.* Л.Харрасова

**ТӘРТИПЧЕ** *и. сир.* Тәртип саклаучы кеше. *Сафны ярып каршысына очтым. Тәртипчегә бирми илтифат!* Ш.Маннур

**ТӘРТИПЧЕЛ** *с.* Тәртип ярата, тәртип таләп итә торган. *Тәртипчел кыз*

**ТӘРТИПЧЕЛЛЕК** *и.* Тәртипчел булу

**ТӘСАДЕФ** *и. гар. иск.* 1) Очрак; очраклылык. *«Саран» дип атаганмын – анысы зур бер тәсадефтер.* Г.Камал. *Бабам, әбием һәм атам, әниемнең – дүртәвенең дә җомга көн вафатлары кызык бер тәсадеф (очраклылык) булды.* Р.Зарипов

2) Туры килү очрагы. *Мөгаллимә илә мөгаллим гыйлем, мәгърифәт, гүзәл холык, тәкъвалык тугрысында берберенә шулкадәр бәрабәр килмешләр иде ки, буйлә рәвештә бер-беренә бәрабәр килгән ир илә хатыннарга дөньяда надир тәсадеф (сирәк очрашу) иде ---.* Р.Фәхретдин. *Көтелмәгән бер тәсадеф бу онытылган җинаятьне тәкрар күз алдына китерде.* М.Гафури

**ТӘСАДЕ́ФӘН** *рәв. гар. иск.* Очраклы рәвештә. *Мәсәлән, катырак җилнең бер агач яфрагын ботагыннан куптарып ташлавы, матур бер чәчәкнең ничек тә тәсадефән аяк аста тапталуы вә гайре шундый җөзьиятнең дә минем күңелемә гади генә бер фаҗига кадәр тәэсир итүе бар иде.* Ш.Камал

**ТӘСАДЕ́Ф ИТҮ** *ф. иск.* Очрау, тап булу; туры килү. *Мәҗмугамыз унынчы яшькә аяк баскан көнләремез, тарихи дошманымыз руслыкның башбаштаклык эчендә чәйкәлгән кызыл русчылыкның чыкмаз тыкрыкка кереп, кая барачагын белмәенчә аптырап калып, кай тарафдан йомрык килә диеб паник эчендә яшәгән көнләренә тәсадеф итәдер.* Г.Исхакый

**ТӘСАДЕ́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәсадеф итү**

**ТӘСАУВЫР** *и. гар. иск.* **1.** Күз алдына китерелгән сурәт, уй-фикер, мәгълүмат, образлар һ.б.; тасвирлар. *Сүзләрнең калынлык, нечкәлек табигате бездә аның мәгънәсе белән, сөйләүченең башындагы тәсаувыр белән бәйләнгән.* Г.Алпаров // Сурәтләү, тасвирлау, гәүдәләндерү эше

**2.** *с. мәгъ.* Күзалланган, фаразланган, гөманланган. *Әмма Аллаһы Тәгаләнең зат шәрифе тәсаувыр гакылдан ерактыр, ягъни Аллаһы Тәгалә андый микән, мондый микән дип күңелгә килгән күзаллауларның һәммәсеннән читтәдер.* А.Тимергалин

**ТӘСАУВЫ́Р ИТҮ** *ф. иск.* Күз алдына китерү, акылда сурәтләү. *Анлар үзләренең җиңелүләрен һич тәсаувыр да итмәгәннәр һәм Истанбулда мәҗрухлар өчен лазем булачак хастаханәләр дә хәзерләмәгәннәр.* Г.Камал. *--- алар [несториан христианнар] Алла – Мәрьям – Гайсә өчлеген бердәй «троица» дип тәсаувыр итүне берничек аңлый алмаганнар.* Н.Максимов

**ТӘСАУВЫ́Р КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәсаувыр итү**

**ТӘСАУВЫФ** *и. гар. дини к.* **суфичылык**. *Тәсаувыф тарафдарларын ул икейөзле булуда һәм ялганчылыкта гаепли, алар кеше алдында үзләрен тәкъва итеп күрсәтергә тырышалар һәм моны бик күп дини булмаган максатларда – дөнья байлыкларын кулга төшерү өчен файдаланалар, ди.* Я.Абдуллин

**ТӘСБИХ** *и. гар.* 1) «Сөбханалла» сүзен әйтү

2) Зикер әйтү, бер үк мактау сүзләрен кат-кат кабатлау өчен, хөрмә җимеше төшләреннән яки борчак рәвешендәге түгәрәк материалдан муенса рәвешендә ясалган тезем; дисбе. *Таибә абыстай күбрәк үзенең бүлмәсендә, сандык өстендә аякларын бөкләп, тәсбих тартып утыра.* Ә.Еники. *Иң имансызлары машиналарында Сөгуд Гарәбстаныннан кайтарылган тәсбих йөртә башлады.* Т.Галиуллин

◊ **Тәсбих анасы** Тәсбихнең һәр 33 төймәсеннән соң куела торган, бер төр зикер сүзеннән икенчесенә күчүне белдергән зур төймә. *Тәсбих анасы --- бер тәсбих сүзеннән икенчесенә күчүне белдергән зур төймә.* Ш.Галиев. *Һәр 33 төймәдән соң тәсбих анасы куела.* Н.Фәттах. **Тәсбих мулласы** Тәсбихнең эре төймәләр тезеп һәм чуклап ясалган башы. *«Тәсбих анасы» һәм «тәсбих мулласы» аңа сан исәбен ялгыштырмаска ярдәм итә.* Н.Фәттах

**ТӘСБИ́Х АГАЧЫ** *и. бот.* Мелиячәләр семьялыгыннан тропик һәм субтропикларда үсә, орлыклары тәсбих ясау өчен кулланыла торган агач үсемлек; *русчасы:* **чёточное дерево**

**ТӘСБИ́Х ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан башлыча Һиндстанда үсә, тропикларда игелә, кызыл орлыклары тәсбих ясауда кулланыла торган агулы үсемлек; *русчасы:* **чёточник молитвенный**

**ТӘСДЫЙК** *и. гар.* Раслау күренеше. *Мәхәллә руханиларын, мәхәллә хадимнәрен тәсдыйк (раслау) яхуд газел (хезмәттән чыгару) хосусларына хөкүмәт идарәләре һичбер вәҗеһ илә (яктан) мөдахәлә итмәс.* Гасырлар авазы

**ТӘСДЫ́ЙК ИТҮ** *ф. кит.* 1) Берәр нәрсәнең яки берәр сүзнең дөреслеген раслау, дөрес дип тану. *Хәзерге вакытта аның киез итек басу производствосына караган уйлап табучылар эше белән шөгыльләнүче комитет тарафыннан тәсдыйк ителгән 12 төрле машинасы гына бар.* А.Алиш. *Минем бурычым, Әхмәдулла энекәш, әлхасыйль, сезгә шуны бәйнә-бәйнә тәсдыйк итү.* Г.Әпсәләмов

2) Нәрсәне дә булса рәсми рәвештә раслау. *«Сез күрсәткән зат шәрифләрне лаеклы санап тәсдыйк итәбез, авыл халкыннан тамга җыеп җибәрегез», – дип язганнар.* Т.Гыйззәт. *Инде бу теләкләр, бу карарларның дәүләт тарафыннан тәсдыйк ителүе калган иде.* Х.Миңнегулов

**ТӘСДЫ́ЙК КЫЛУ** *ф. кит. к.* **тәсдыйк итү**. *Дүрт имамны тәсдыйк кыйл.* К.Насыйри. *Бу эш миргә каршы, мөселман галәме моны тәсдыйк кылмаячак.* Х.Камалов

**ТӘСДЫЙКЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **тәсдыйклау**. *Аннары шул тәсдыйкланган гаризаларны җирле комитет утырышы аша уздырыр.* Х.Камалов

**ТӘСДЫЙКЛА́У** *ф.* Раслау, дөресләү, тәсдыйк итү. *Менә шушы белгәннәремне, әйткәннәремне имзам белән тәсдыйклыйм.* Р.Мостафин. *Шунысын да искәртик: Татарстан Диния нәзарәте тәсдыйклаган карар белән, бары ике генә югары мәдрәсәне тәмамлаган шәкертләр Россия ислам университетына кереп укуларын дәвам итәргә хокуклы.* Ватаным Татарстан

**ТӘСЕЛЛЕ** *с. диал.* Җитез, сәләтле, булдыклы, оста, соллы. *Тәселле егет*

**ТӘСЛИМ** *и. гар.* 1) Кулдан кулга тапшыру, бирү; берәр нәрсәне иясенә кире кайтарып бирү гамәле. *Шул сәбәптән Аллаһы Тәгаләнең казасына тәслим булудан башка чаралары юк.* Гасырлар авазы

2) Бирелү, тапшырылу, каршы торудан туктау, җиңелүне тану күренеше. *Фәкать шуны уйладым: мин дошманга тәслим булырга китеп баручы һәм иртәгә язмышымның ничек буласы билгесез бер сәяси «җинаятьче» идем, Зәки Вәлиди исә махсус поезд белән мәмләкәтенә кайтып баручы «дәүләт кешесе» иде.* Г.Баттал. *Шәһәр тәслиме вакытында бик күп кан коелды.* Мирас

**ТӘСЛИ́М ИТҮ** *ф. иск.* Берәр җанлы-җансыз нәрсәне яки кешене икенче берәүгә тапшыру, бирү. *«Ялт-йолт» журналының секретарьлыгын башка кешеләргә тәслим иттем.* Г.Тукай. *1919 елда Сибириядә «соң язган китабым» дип артист Абдулла Каригә тәслим итеп китүен сөйләр иде.* Г.Исхакый

**ТӘСЛИ́М КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәслим итү**. *Габдуллага сатып, акчасын кабыз кыйлып, җарияне тәслим кыйлганнан соң, җариясе --- бу бәетне укыды.* К.Насыйри

**ТӘСНИФ** *и. гар. иск.* Язу-сызу эше, язучылык, иҗат. *«Ядкәр» – Мөхәммәдсәлим бине Ишмөхәммәд Өмидбаевның тәснифләреннән.* Х.Бәдигый

**ТӘСНИ́Ф ИТҮ** *ф. иск.* Китап, әдәби, фәнни әсәр язу; иҗат итү. *«Тәсниф итте» дигән сүз генә аңлашыла, авторы кем икәнлеге күренми.* Татарстан яшьләре

**ТӘСНИ́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәсниф итү**. *--- укыгач, сөрур хасыйль була торган бер китап тәрҗемә итеп яки тәсниф кылып бирсәңез иде ---.* Ф.Халиди. *[Хезмәт] Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды.* К.Насыйри

**ТӘТӘ** *и. диал.* 1) Бертуган кыз кардәш, апа. – *Харам мал төс бирми, тәтә, – диде энесе, ерактанрак суктырып.* М.Әмирханов

2) Әтинең яки әнинең бертуган сеңлесе, тута, түти. *Нәкъ шул минутта иң кече кыз – яланаяклы кара тәпиле кыз – төз лапас астыннан йөгереп чыгып, чырыйлап кычкырды: – Тәтә үлә! Тәтә үлә!* М.Мәһдиев

3) Әби, дәү әни. *Безнең тау ягында өлкән яшьтәге әбиләрне, дәү әниләрне күбрәк «тәтә» дип йөртәләр.* Р.Сәгъди

4) Гомумән олы яшьтәге хатын-кызга хөрмәт итеп эндәшү сүзе. *Гөлүсә авырып китте бит әле, Зәйтүнә тәтә.* М.Хәсәнов. *Килгән саен алар: «Әйдә, тәтә, чәй эчик әле», – дип, әби янына керәләр.* В.Нуриев.

5) *диал.* Балаларга, яшьләргә «бәпкәм», «җаным», «наным» мәгънәсендә яратып, иркәләп әйтү өчен кулланыла торган сүз. *Тәтәм, алай ярамый, әниеңнең сүзен тыңларга кирәк.* Кызыл таң

6) *диал.* Әти. *[Анна:] Без әти димибез, тәтә дибез.* А.Гыйләҗев

**ТӘ-ТӘ** *иярт.* 1) Кечкенә балалар чыгарган авазларны белдерә. *Минем энем: тә-тә-тә, сөйли-сөйли йөдәтә, сорый-сорый йөдәтә ---.* Г.Әпсәләмов

2) Берәр кешедән көлгән вакытта әйтелә. *Агайлар тагы да яманрак шаулап, ачулы-зәһәр итеп көлергә тотыналар: «Их-хи-хи! Тә-тә-тә! Ну, Хәбиб!»* Ә.Еники. – *Тә-тә-тә, – дип, яткан җиреннән сикереп торды Җик Мәргән.* М.Хәбибуллин

**ТӘТӘЙ** I *и. сөйл.* 1) *к.* **тәтә** (*1 мәгъ.*). – *Курыкма, тәтәй, имгәнмәс, утырып, ныгып кына китәр, – диде егет һәм тамак кырып куйды.* Ә.Еники. *Әле күптән түгел, үзе дөнья куйганнан соң кырык ел үткәч, Латыйфә тәтәй исеменең мәгънәсен укыдым да исеме җисеменә шулкадәр туры килер икән дип хәйран калдым.* Ш.Галиев

2) *диал. к.* **тәтә** (*2 мәгъ.*). *Тәтәй ашка сала иде, бөтнек кыркып кергәннәрем гомергә истә калган.* Ш.Галиев

3) *күч. сөйл.* Фахишә, бозык хатын-кыз. *Никадәр охшаш заман килгән, Никадәрле азык язарына: Һәр чат саен яшь тәтәйләр баскан, Иңнәренә нәни сумка аскан.* Җ.Дәрзаман. *Казанның татарлар телендә Искәндәр сарае дип йөртелгән Александр пассажына җигүле ат белән кереп, тәтәйләр янында атналар буена калып, ахырда ак ыштаннан гына чыгып качкан вакытлары да аз булмады.* Ф.Яхин

◊ **Тәтәйләр йорты** Фәхешханә, кызыл фонарьлы йорт. *«Дөмбер карчык йорты» – Иске Казанда гадәттә*

*татар бәндәсе токан фәхешханә, сәфаләтханә, тәтәйләр йорты.* А.Тимергалин. *[Кара жиләнле:] Үзең дә беләсең, аның өчен тәтәйләр йорты бар.* Р.Зәйдулла. **Тәтәйләр рәте** *к.* **тәтәйләр йорты**. *Гүзәл хатыны, күз карасыдай баласы – «алтыны» булса да, ул – әхлакый яктан бозык һәм азгын кеше: унбишләп хатын алган, өстәвенә, кичләрен Кабан күле буендагы фәхешханәгә – «тәтәйләр рәте»нә йөргән.* Р.Ганиева. **Тәтәй чаба, мин дә чабам** Кеше ихтыярына буйсынып, ияреп эшләү (мөстәкыйль фикерле булмаган кешегә карата әйтелә). *Шуңа күрә «тәтәй чаба – мин дә чабам» дип, чит ил тәҗрибәсен тоташы белән үзебезгә күчереп булмый.* Ватаным Татарстан

**ТӘТӘЙ** II *и. сөйл.* **1.** 1) Матур, әйбәт, кызыктыргыч әйбер. *Аның кешеләре, чыннан да, Изгеавылны басып алдылар: авылда көне-төне сыйланулар, сыйлаулар китте, сәбәпле-сәбәпсезгә очсыз бүләкләр, ялтыравык тәтәйләр тарату башланды.* Ф.Бәйрәмова

2) Балалар җыеп уйнарга ярата торган пыяла, фарфор һ.б. кисәкләре ише вак-төяк ялтыравык әйберләр; тәти. *Чәче дигәндә ул аллы-гөлле тасмаларга катып-корышып беткән бармак битләре белән кагылып алды, алка дигәндә – җиз кисәкләренә, муенса дигәндә таш, тәтәй кисәкләренә кагылгалады.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ. сөйл. к.* **тәти** (*2 мәгъ.*). *Аның телефоннар, тәтәй кара савытлары куелган өстәл артында утыруларын күрсәгез, шаклар катар идегез инде менә!* М.Хәсәнов. *Коммунизм кәкәй түгел, тәтәй ул!* Ф.Баттал

**3.** *рәв.* Үз аягы белән, чит ярдәмсез (кечкенә баланың басып торуы, йөри башлавы тур.). *Ул хәзер бишегеннән чыгып килә инде, сәке буйлап үрмәләгән була, ике кулыннан тотып бастырсаң, тәтәй тора.* Ш.Маннур. *Тәтәй йөрү*

**ТӘ-ТӘ КИЛҮ** *ф.* Бертуктамый күп сөйләү; артык әрсез сөйләшү, тел озайту. *– Өч-дүрт кило ит биреп кенә котылырмын дип уйлама! – дип, Ихласның күзен ачырмыйча, тә-тә килеп утыра, сасык!* А.Гыйләҗев. *Ул тә-тә килеп гел сөйләп тора: фәлән-фәлән кешеләр белдерү аша танышып кушылдылар, ди, фәләннәр гөрләшеп яшиләр, ди, фәләннәрнең, шулай өйләнешеп, ике балалары бар, ди.* Ф.Садриев

**ТӘТӘЛ** *и.* 1) Ятьмәне, елымны суда киерү җайланмасы; тәтәлкә. *Алар елга буендагы таллыктан кармак сабы ясап, кипкән камыштан тәтәл рәтләп, балык тотарга да тотындылар.* Л.Таналин

2) *күч.* Төенчек. *Кулында кечкенә генә бер тәтәл иде.* И.Нуруллин

**ТӘТӘЛКӘ** *и. к.* **тәтәл**. *Балык түгел, дулкын уйната тәтәлкәне.* М.Хуҗин. *Кармакка җим каптырып, тәтәлкәле җепне суга ыргытканнан соң, бераз гына сүзсез утырдылар.* Р.Низамиев

**ТӘТӘЛЛЕ** *с.* 1) Тәтәле булган. *Тәтәлле ятьмә белән без ике-өч сәгать эчендә бер чиләк балык тотып кайттык.* Г.Ахунов. *Ә яздан башлап кара көзгә хәтле, эштән соң, Атыш елгасында тәтәлле ятьмә белән балык тота.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Үзенә ияреп йөрүчесе булган. *Тәтәлле егетләр*

◊ **Тәтәлле бозау койрыгы** Чәч толымы. *Чәч дисәң дә чәч инде аның – тәтәлле бозау койрыгы ---.* Ватаным Татарстан

**ТӘТӘ́Л ТАШЫ** *и.* 1) Балык тота торган ятьмәгә тагылган таш яки башка авыр нәрсә; батыргыч. *Тәтәл ташы суга төшеп киткән икән, күрми калганбыз.* Ш.Маннур

2) *күч. шелт.* Кемгә дә булса ияреп, бер адым да калмый тагылып йөри торган кеше. *– Аның кадәр үк тәтәл ташы булмасаң инде, – диде дә ишекне дә япмыйча чыгып китте апасы.* Г.Әпсәләмов

3) *күч. шелт.* Бертуктаусыз һәм күп сөйләшүче кеше; лыгырдык. *[Сөбхи:] Лыкылдама, тәтәл ташы.* М.Фәйзи

**ТӘТӘ́Ү** *и. диал.* Әти. *Тәтәү ягыннан бабаларымның бер агай-энесе Франциягә походтан, Париждан үзенә хатын алып кайткан.* Безнең мирас

**ТӘТЕ** *и.* Мылтык, пистолет һ.б.ш. ату коралында бәрмә механизмның бер детале; чакма. *Куян мушкада! Тәте әкрен генә артка шуыша!* Р.Батулла. *Өченче тапкыр чүмырып алганда, болганчык суга ияреп, мылтык өстенә ниндидер тимер кисәге тәгәрәп төште – тәте иде ул!..* Д.Әхмәтова

**ТӘТЕК** *с.* **1.** *диал.* Кыска буйлы һәм җитез хәрәкәтле. *Тәтек кенә бер малай булганмын кечкенә чакта.* Кызыл таң

**2.** *и. мәгъ.* Механизмның, җайланманың аерым бер өлеше, деталь. *Катапультаның аерым тәтекләре (детальләре) – кереш, таразы, каба һ.б.* Р.Әхмәтьянов

**ТӘТЕЛДӘВЕК** *с. к.* **тәтелдек**. *Минем әти дә, мөгаен, атыннан да, тәтелдәвек төпчегеннән дә арынып, бераз ял итеп алырга уйлагандыр.* К.Миңлебаев. *Баштан әби сабыр гына тәтелдәвекнең аруын көткән, аннан туктыйсыңмы, дип ачуланып алган, тәмам тәкате беткәч, катырак сүзләр дә ычкындыргалагандыр инде.* Ә.Галиева

**ТӘТЕЛДӘ́Ү** *ф.* Тиз-тиз сөйләү; вак-төяк, юк-бар нәрсәләр турында күп сөйләү. *Менә хәзер сине алдыма утыртып, синең тәтелдәгәнеңне ихлас күңелдән тыңлау мөмкинлеге өчен җаным фида кылырга да риза булыр идем.* К.Миңлебаев. *– Ие, ие, – дип тәтелдәде Сафура, – җырлауның ояты юк аның.* Х.Ибраһим

**Тәтелдәп алу** Бераз гына тәтелдәү. *Сәгыйдулла икенче бүлмәгә чыккан арада, Саҗидә колак төбемдә автоматтай тәтелдәп алды: – Тегe эт ашамас, песи яламас нәмәрсәгә «Казаннан китте» диген.* Ф.Баттал

**Тәтелдәп тору** Сөйләү моментында тәтелдәү; гел тәтелдәү. *Ата белән ананың тырышлыгы бушка китмәде: балалар татарча бер сүз белмәсәләр белмәде, ну урысчаны тәтелдәп торалар иде инде.* Р.Сәгъди. *– Булды, булды, барысы да булды, – дип тәтелдәп торды кызыкай.* К.Кара

**Тәтелди башлау** Тәтелдәргә тотыну. *Шул җан иясенә карап алдылар да, алдан ук сүз куешкандай, тиз-тиз генә тәтелди башладылар: – Дөнья пычратып йөри бит бу...* Ф.Баттал. *Төенчек күтәреп чыгып килгән Вәрәкыяне күргәч, каушапмы, уңайсызланыпмы, тагын үзалдына сөйләнгәндәй тәтелди башлады: – Борчылмаслыкмыни?! Авылыгызга туры юлдан – Зәхмәт күле аша гына килдем.* Р.Рахман

**Тәтелди бирү** Бернигә дә карамый тәтелдәү. *Ул минем бу сүзләремне колагына да алмады: – Я, нинди билге белән котлыйм сезне, «отлично» беләнме? – дип, һаман үзенекен тәтелди бирде.* В.Нуруллин. *[Кыз] Бәләкәй бармагын сәхнә ягына төртеп тәтелди бирде: – Дошманнар әнә тегендә, шуларны куарга кирәк.* Ф.Сафин

**ТӘТЕЛДЕК** *с.* **1.** Күп сөйләшергә яратучан (күбесенчә хатын-кыз һәм балалар тур.). *Нинди генә җитди булып күренергә тырышмасын, бигрәкләр сагынып кайта иде шул тәтелдек малаен.* К.Миңлебаев. *Шундый йомшак, шулкадәр сагынылган һәм шултикле кадерле иде аның, алты гына яшьтә булса да, зурларча акыллы, тәтелдек Розалиясе!* В.Нуруллин

**2.** *и. мәгъ.* Күп сөйләүче, бертуктаусыз тәтелдәп торучы кеше. – *Аһ, тәтелдекләр! Сез лыбырдашканда, сөт үзеннән-үзе чиләккә ага мәллә?! – дип, абзарга «күз һәм колак» керде.* Н.Гыйматдинова. – *Иркә ише тәтелдекләр – бәхетсез җаннар ул, – дидем.* Безнең гәҗит

**ТӘТЕ́Л-ТӘТЕЛ** *рәв.* Бертуктаусыз, күп, тиз-тиз (сөйләү, сөйләшү тур.). *Тәтел-тәтел утырма, Үзең өйрән укырга!* Ш.Галиев. *Тәтел-тәтел сөйләп торуы да рәхәт...* М.Әхмәтшина

**ТӘТЕЛ-ТӘТЕ́Л КИЛҮ** *ф. к.* **тәтелдәү**. *Тәтел-тәтел килеп көннәр буе утырырга мөмкин ул, аны тыңлап торсаң, бер эш тә эшли алмыйсың.* Кызыл таң

**ТӘТИ** *с.* **1.** 1) Балалар телендә: матур, чибәр, ямьле, әйбәт. *Ә балалар, тәти күлмәк кидермәсәң, фотога төшәргә теләми.* Ф.Яруллин. *Кая, тәти күлмәгеңне кидерәм.* М.Әхмәтшина

2) *сөйл.* Яхшы, әйбәт. *Югыйсә әсәрләрендәге Сталин, Хрущёв, Брежнев исемнәрен сызып ташлап, тәти булып калырга тырышучылар күренә башлады.* Ф.Җамалетдинова. *Аннан килеп, укучыга, тәти сүздән бигрәк, төгәл сүз кыйммәт.* Р.Фәйзуллин // Шәп, матур. *Тәти товар*

3) Туган абый һәм апаларга иркәләп, яратып эндәшкәндә «абый», «апа» сүзләреннән алда әйтелә торган сүз. *Ни хәлләр соң, тәти абый? Авылда һавалар әйбәттер?* М.Мәһдиев. *Матурлык җәһәтеннән, минем фикеремчә, беренче укытучым Рәисә ападан чүт-чүт кенә кайтышрак, кушаматы да Тәти апа, Разия апаны күргән-белгән кеше башкача уйлый да алмас.* Т.Галиуллин

4) *шелт., ирон.* Эшләргә бик яратмыйча, матур киемнәр киеп көязләнеп йөрүче, кыланчык; бизәнеп йөрергә яратучы. *Тәти егет, хәзер гаепле кешене эзлисең, син үзең йөрдең Хәмзин дә Хәмзин дип, авыз ерып.* И.Юзеев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Матур, ялтыравыклы уенчык. *Анна Васильевна, тәтиләрен күрсәтә торган бала кебек, иң әүвәл Шәмсигә дачаны күрсәтте.* Г.Исхакый. *Бала күз явын алырлык тәтиләргә дә, шул уенчыклар тирәсендә бөтерелгән яшьтәшләренә дә карамый.* Н.Нотфуллина

2) Ватылган чынаяк кыйпылчыгы, чынаяк китеге. *[Күл] төбендә саф ахак кебек Таш тәтиләр ята елтырап.* Б.Рәхмәт. *[Гөлсемнең] бик кадерле күргән матур бизәкле чынаяк тәтие [бар].* Г.Гобәй

3) Кадерле, яраткан кеше. *Көне буе икегезне дә сагынып беттем инде, әй тәтиләрем минем!* Р.Сәгъди

**3.** *рәв. мәгъ.* Яхшы итеп, әйбәт итеп. *Әгәр мин аңа минем белән ничек тәти уйнавыңны барып сөйләсәм...* Г.Әпсәләмов. – *Кунаклар килгәч, кем үзен тәти тота, шуңа иң тәмлеләрен бирермен, – дип, әниләре кисәтеп куя...* Г.Галиева

◊ **Тәти кош** *сөйл. ирон. к.* **асыл кош**. *Бу артык матур, артык зифа яшь врачка алар шикләнеп карыйлар: каян очып килгән бу тәти кош, берәр түрәнең капризлы кызымы я булмаса кәләшеме, диләр төсле.* Г.Әпсәләмов. *Директор да аны күрде һәм, ә-ә, тәти кош, бу синмени әле дигәндәй, ризасызлыгын йөзенә чыгарып, чыраен сытты.* М.Хәсәнов. **Тәти кул** Уң кул (балалар телендә). *Кашыкны тәти кулыңа тот.* Н.Гыйматдинова. *Без кызлар белән аңа чишмәдән су алып кайтабыз, идәнен юабыз, өен җыештырабыз, аннары ул безнең барыбызга да: «Тәти кулың кайсысы?» – дип сорый-сорый я чикләвек, я конфет өләшеп чыга да озын-озын итеп рәхмәтләр укый.* Н.Кәримова. **Тәти күрсәтү** Юмалап, буш вәгъдәләр биреп алдау, нәрсә белән дә булса кызыктыру. *Яшь балага тәти күрсәтеп кызыктырган кебек, староста калай медаленә кызыңны алмакчы булганнар бит.* Т.Гыйззәт. **Тәти тоттыру** *к.* **тәти күрсәтү**. *Тәти тоттырып кына алдый алмассың, хәзер ул элеккеге тәҗрибәсез белгеч түгел инде.* Мәйдан

**ТӘТИБИ** *и. диал.* Бернинди файдалы эш белән дә шөгыльләнмичә, киенеп-ясанып йөрергә генә ярата торган кеше. *Аннары икенче тавыш белән өстәде: – Тәтиби егетләрнең серкәләре су күтәрми икән.* Г.Әпсәләмов

**ТӘТИБИКӘ** *и. сөйл.* Киенеп-ясанып йөрергә генә ярата торган көяз хатын-кыз. *Андый тәтибикәләр күп булыр, барысына да күз салырга димәгән ---.* Р.Вәлиева

**ТӘТИБИЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Киенү-ясану белән артык нык мавыгу. *Тәтибиләнеп кенә тормыш алып барып булмый*

**Тәтибиләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында тәтибиләнү; хәзерге вакытта тәтибиләнү

**ТӘТИКИГӘВЕН** *и. сөйл. к.* **камка** I. *Тәтикигәвеннәр мыж килә*

**ТӘТИКӨПШӘ** *и. бот. к.* **тубылгы**. *Безнең әби тәтикөпшә үләнен күп итеп җыеп куя да салкын тигәндә һәм буыннар сызлаганда куллана иде.* Р.Вәлиев

**ТӘТИЛӘНҮ** *ф. сөйл.* 1) Матурлану, ямьләнү, тәтигә әйләнү, тәти булу (гадәттә балалар телендә яисә балалар белән сөйләшкәндә). *Сеңлемне кочаклап алды да: «Бигрәк тәтиләнгән икән кызыбыз», – дип елмайды әти.* Сабантуй

2) Бизәнү-ясану белән генә мәшгуль булу; матур яки яхшы күренү, уңай тәэсир калдыру өчен тырышу. *Хәер, нигә дип шул тиклем тәтиләнергә әле.* К.Кәримов

**Тәтиләнеп китү** Тагын да тәтиләнү. *Бу күлмәкне кигәч, син тагын да тәтиләнеп киткән.* Р.Вәлиева

**Тәтиләнеп тору** Хәзерге моментта тәтиләнү; озак тәтиләнү. *Колакка килеп чалынган иң саран хәбәрләргә караганда, кемнең кем булуына карамыйча, бу йортта бер генә кеше белән дә тәтиләнеп тормыйлар.* Ф.Сафин

**Тәтиләнеп утыру** *к.* **тәтиләнеп тору**. *Шундый чакларда да «әдәп саклап», тәтиләнеп утырсак, я, без үзебез кем булабыз инде?* Р.Шәрәфиев

**ТӘТИЛЕ** *с. сөйл.* **1.** Ниндидер матур әйберләре, бизәкләре булган, үзенчәлекле, күңелгә хуш килә торган. *Синең тәтиле тәбригеңне алдык.* Рухи мирас – эзләнүләр һәм табышлар

**2.** *и. мәгъ.* Тәтиләр, чынаяк китекләре белән уйнала торган балалар уены. *Кичә төнгә кадәр кызлар белән тәтиле уйнады бит ул!* Д.Булатова

**ТӘТИЛЕК** *и.* 1) Ялтыравык матурлык; ясалма матурлык. *Башкортстан җитәкчелеге белән мөнәсәбәтләрдәге тәтилек андагы татарлардан йөз чөерү исәбенә булырга тиеш түгелдер ул.* Д.Исхаков

2) Тышкы матурлык. *Тәтилегенә кызыкма*

**ТӘТИ-МӘТИ** *и. сөйл. шелт.* Ирләр яки хатын-кызлар белән чытлыклану, шаяру. *Тәти-мәтиләр килешә торган вакытмени?* Кызыл таң

**ТӘТИТАРАКАН** *и. к.* **камка** I. *Яз башы җитүгә [агач төпләрен] кара төрткеле, кызыл канатлы бөҗәкләр сырып алалар. Халык телендә «тәтитаракан» яки «камка» дип йөртелә торган бу коңгыз кайчандыр Фатыйма исемле бик матур хатын булган, имеш.* К.Нәҗми

**ТӘТ-ТӘ** *иярт.* Сөйләшергә өйрәнеп килгән балалар чыгара торган авазлар. *Әт-тә, ән-нә, тәт-тәт-тә!.. Әб-бә, баб-ба, тәт-тәт-тә!.. Айдар шулай матур итеп Үз телендә сөйләшә.* Э.Мөэминова. *Матурларны таный ул үзе дә – Җиңгәләрне: «Апа, тәт-тә!» – ди ---.* Г.Садә

**ТӘТ-ТӘТ** *рәв. к.* **тәтәй 3**. *Улым, әйдә инде, тәт-тәт йөрибез.* Р.Вәлиева

**ТӘТҮ** *ф.* Кемгә дә булса берәр нәрсә эшләргә һ.б. насыйп булу, мөмкинлек чыгу. *Бер уйласаң, гаиләле булу бәхете аңа утызга якынлашканда гына тәтеде.* С.Шәрипов. *Ходайга шөкер, ике ул үстердек, әзгә генә булса да, онык сөю бәхете дә тәтеде миңа.* Г.Якупова

**Тәти башлау** Тәтү очраклары ешаю. *Әйе, балет артистларына соңгы вакытларда гына тәти башлаган бик тансык һәм кадерле сәфәр иде бу.* Р.Вәли. *Башта өйдәгеләрен, якыннарын сыйласа, соңрак татлы ризыкны авыз итү мөмкинлеге күрше-күлән, туган-тумачаларга да тәти башлый.* Безнең гәҗит

**ТӘ-ТҮТ** *иярт. к.* **тү-тү**. *[Сәминең] бәхетенә бик кызыгам, чөнки миңа хәзер укулар – тә-түт!* Ш.Маннур

**ТӘ́Ү** *с.* **1.** Беренче, әүвәлге; тәүге. *Кеше үзенең кемлеген, асылын, нәселнәсәбен тирәнрәк белер өчен, берчак тәү чыганакларга, үткәнгә әйләнеп карый.* Г.Хөсәенов

**2.** *рәв. мәгъ.* Иң беренче тапкыр, әүвәл, башта. *Гомердә тәү күргән кешеләр дә әллә кайчан таныш булган кешегә әйләнә.* Н.Нәҗми. *Сабиров кабинетының иң түрендәге ишекне Гөлзилә тәү кергәндә искә алмаган икән.* М.Кәбиров

**ТӘҮБӘ** *и. гар.* **1.** Кылган гөнаһка яки гаеп эшкә үкенү һәм аны яңадан кабатламаска карар кылу, сүз бирү. *Хата белән хатаның, тәүбә белән тәүбәнең аермасы да кайчак җир белән күк арасы.* Г.Хөсәенов

**2.** *ы. функ.* 1) Берәр яман яки гөнаһлы эштән яки сүздән кайтканда, аны башка эшләмәскә карар биргәндә әйтелә. *– Тәүбә, бүтән булмас, начарлыгым тигән булса, гафу итегез, хушыгыз, – дидем.* Ә.Баян

2) Гомумән берәр сүз белән катгый килешмәү, ошатмау һ.б.ш. белдерә. *Тәүбә, мәктәптә укытып ми черетәмме соң, тәүбә!* Н.Гыйматдинова

◊ **Тәүбәгә килү** *к.* **тәүбә итү**. *Муеннан гөнаһларга батабыз да... аннары, авыз күтәреп, гафу итүеңне үтенәбез, тәүбәгә килмәкче булабыз, сине искә төшерәбез...* З.Хөснияр. *Бурайга кайткач, Мирхан, чыннан да тәүбәгә килеп, адәмчә яшәргә ният иткән икән.* З.Мурсиев. **Тәүбә (догасы) укыту** Моннан соң ул эшне эшләмәскә ант иттерү. *– Тәүбә догасы укытырга кирәк, бөтенләй азына башлады алайса, – ди әнә абыйсы да.* Кызыл таң. **Тәүбә капкасы (капусы) ябылу** Моңарчы эшләгән яман эшләре яки әйткән начар сүзләре өчен үкенеп, хаталарын танып, аларны яңадан кабатламаска үз теләге һәм акылы белән сүз бирү вакыты үтү; тәүбә итәргә соң булу. *Монда инде алдынгылар рәтендә шул ук тәүбә капкалары ябылган Гаязлар, я кайчандыр дөнья кендеге булып йөреп, җил-давыл китереп ташлаган зур бавырлы акыл ияләре.* Ә.Хәсәнов

**ТӘ́ҮБӘ-ӘСТӘГЪФИРУЛЛА** *ы.* Ялгышканын, нәрсәнедер дөрес эшләмәвен яисә хаклы булмавын аңлаганда әйтелә. *Нәрсә, мин ялганлыйммы? Тәүбә-әстәгъфирулла, диген!* Т.Гыйззәт. *Октябрь бәйрәмнәре җиткәч, кечкенә кызым – Резедам әйтә миңа: – Әтием, туйдым инде мин бу хатыннар базарыннан (үз сүзләрем икән монысы, тәүбә-әстәгъфирулла!), үзең белән ял йортына алып бар әле? – ди.* Ж.Дәрзаман

**ТӘҮБӘ-ИСТИГЪФАР** *и. дини* Кылган гөнаһлары өчен үкенеп, чын күңелдән тәүбә итү һәм Аллаһның ярлыкавын сорау гамәле. *Менә бүген, тәүбә-истигъфар көнендә, Мәхмүтов бөтен тормышын күз алдыннан кичерде: ничек яшәгән, ничек эшләгән, намусы чистамы?* Р.Мирхәйдәров. *Гөнаһларның тәүбә-истигъфар юлы белән кичерелүендә зарарлы, яман ялган күрәм, мондый эшләр әдәпсезлекне, әхлаксызлыкны арттыра һәм гөнаһ кылудан курку хисен юкка чыгара.* Безнең гәҗит

**ТӘҮБӘ-ИСТИГЪФА́Р ИТҮ** *ф.* Кылган гөнаһлар өчен үкенеп, тәүбә итү, Аллаһның кичерүен сорау. *Тәүбә-истигъфар итегез, күңел сабакларыгызны яңартыгыз!* Г.Камал

**ТӘҮБӘ-ИСТИГЪФА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тәүбә-истигъфар итү**. *Хөсникамал апа кемне югалтканын, изге улына бәддога укып ялгышканын аңлагач, Аллаһы каршында ничәмә-ничә мәртәбәләр тәүбә-истигъфар кылды.* Ф.Яхин. *Иң элек тәүбә-истигъфар кылырга, фарызлардан тыш нәфелләрне дә үтәп, калебне чистартып, тәртипкә китерергә кирәк.* Мәдәни җомга

**ТӘҮБӘ́ ИТҮ** *ф.* Берәр ярамаган эш, гөнаһ эшләүгә үкенеп, аны яңадан кабатламаска сүз бирү. *Тәгъбирчеләр куркыныч төшләр күреп саташкан кешегә гөнаһларыннан тәүбә итеп, хәерсадака биреп, бозык эшләрдән ерак булырга киңәш итәләр.* А.Тимергалин.

*Тәүбә итмә, кеше, хыянәттән соң, Кыл ялганмый намус артында.* А.Хәлим

**ТӘҮБӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **тәүбә итү**. *Мenә хәзер баягы күңел гөнаһым өчен намаздан соң тәүбә кылдым.* Г.Исхакый. *Гөнаһлардан тәүбә кылдым димим, Холкым үзгәрешле, диюем.* И.Сабиров

**ТӘҮБӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәүбә сүзләре әйтү, тәүбә итү. *Гайнан тәүбәләде, бүтән эчмим, ди.* Н.Гыйматдинова

2) Гомумән, берәр эшне башка кабатламаска сүз бирү. *Килгән саен, Сөмбелә: «Бүтән бармыйм!» – дип тәүбәләп кайта.* К.Кәримов

**ТӘҮБӘЧЕЛ** *с.* Еш тәүбә итүче; тәүбә итәргә яратып, гадәттә сүзендә тормаучан. *Яман суфи – тәүбәчел, яман адәм – хәрәмчел.* Мәкаль. *Тәүбәчел кешеләргә шикләнеп карыйм мин.* Мәдәни җомга

**ТӘҮГЕ** *с.* Иң беренче, әүвәлге, элекке, баштагы. *Дөрес, ул күзгегә карап тормады, хәер, алтынсу маңгай чәче каплаганга, сызылып кына килгән тәүге җыерчыкларны ул барыбер күрмәгән булыр иде.* А.Тимергалин. *Тормышымны тәүге кардай ап-ак, чиста биттән башлар өчен, үз-үземнән качып, бик ерак, бик озын юлга чыктым мин.* Р.Габделхакова

◊ **Тәүге әтәч** Иртә таң вакыты, таң яңа гына беленә башлаган вакыт. *Безгә бары тәүге әтәчкәчә Кирәк иде йоклап алырга.* М.Җәлил. **Тәүге әтәч белән** Таң беленә башлауга ук, бик иртә. *Габделҗәмил, тәүге әтәч белән торып, калага печән сатарга китәргә тиеш иде.* М.Кәрим. **Тәүге карлыгач** Нинди дә булса эштә, өлкәдә беренче булган, башлап җибәрүче; көтеп алынган беренче хәл, күренеш һ.б. *Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман» газетасы – татар вакытлы матбугатының тәүге карлыгачы.* Х.Миңнегулов. *Шушы фестивальдән соң театрыбызның тәүге карлыгачларының берсе Рима Шәһит кызы Ключарёва беренчеләрдән булып Башкортстанның атказанган артисткасы исеменә лаек булды.* Сәхнә

**ТӘҮДӘ** *рәв.* Иң элек, иң башта, башлап; беренче эш итеп. *Ул төшенчә минем аңыма иң тәүдә Маяковский исеме белән килеп керде, аннан соң инде «Тукай традициясе» дигән төшенчә аңыма сеңде.* Н.Нәҗми. *Бу җеп һәм бу тәм күзгә күренми, телдә тоелмый башласа, иң тәүдә телнең, аннан илнең үзен үлем биләп ала.* А.Хәлим

**ТӘҮЛӘП** *рәв.* Беренче тапкыр, беренче кат, әүвәл. *Тәүләп килдем Иҗат йортына.* С.Рәхмәтулла. *Айсылу апаларының да ул шәһәргә тәүләп баруы ласа.* Г.Якупова

**ТӘҮЛЕК** *и.* 1) Бер көн һәм бер төнне эченә алган егерме дүрт сәгатьлек вакыт берәмлеге. *Ике тәүлек дигәндә, сау-сәламәт бала туды.* М.Мәһдиев. *Сорау алулар берничә мәртәбә, туктамастан өчәр тәүлек дәвам итә.* З.Зәйнуллин

2) *Ел, ай, көн* кебек сүзләр белән килеп, шуның «тулы циклы», «әйләнеше, әйләнәсе» мәгънәсен белдерә. *Ел тәүлеге авылларда кеше өендә кунып йөри.* М.Мәһдиев. *Миңа, примерга, әбиеңнең көн тәүлегендә ким дигәндә бер, биюче әртист була алмадым, дип зарланмаганы юктыр.* Р.Хәмид

◊ **Тәүлекнең алтынчы намазы** Билгеләнгән күләмнән тыш һәркөн үтәлүе мәҗбүр булган өстәмә эш, бирем. *Ул хәзер аңа тәүлекнең алтынчы намазы кебек карый бит инде.* Сөембикә

**ТӘҮЛЕКЛӘП** *рәв.* 1) Эш, кизүлек итү һ.б.ш.ның вакытын тәүлек белән билгеләп. *Дүрт йорттагы дүрт гаилә тәүлекләп дежур торып, комлы сахра җиренә арыклар буенча су агызалар.* Ә.Гали. *Алар шулай вакыты белән тәүлекләп эшлиләр.* Т.Галиуллин

2) Бер тәүлек чамасы. *Үзе ул преферанс сугарга ярата, кайдадыр хәрбиләрдән һәм карт артистлардан якалашып уйный торган кешеләре бар, шулар янына китсә, тәүлекләп тә югала торган иде.* Ә.Еники. *Көнләп кенә түгел, тәүлекләп китмәделәр нефтьчеләр яңа скважиналардан.* З.Мәхмүди

3) Тәүлек исәбе белән. *Күчеп килү өчен юл акчалары, прорабның хезмәт хакын – йөз кырык сум, тәүлекләп түләнә торган акчаларны бирделәр, шуңа күрә кесәм буш түгел.* Р.Мирхәйдәров

**ТӘҮЛЕКЛЕ** *с.* 1) Тәүлек белән исәпләнә торган, тәүлекләргә бүлеп эшләнә торган. *Габдулла тәүлекле эштә кәчәгәрдә, мин беренче бала белән больнискә кергән идем.* Н.Хәсәнов. *Казанда тәүлекле эшләрдә эшләп, ял көннәрендә авылдагы йортларына кайтып, дачада ял иткән кебек яшәп, тагын шәһәргә тәүлеккә китеп баручылар күп бездә.* Татарстан яшьләре

2) Сан белән килгәндә, шул сан белән күрсәтелгән тәүлеккә сузыла торган. *Танибәкне Сарай Бәркәдән ике тәүлекле юл арасындагы Сарайчык каласына чаклы каршы барып уен ясадылар.* В.Имамов. *Монда килүенә әле тулыр-тулмас ай ярым вакыт узды, инде өченче тапкыр штраф изоляторында унбиш тәүлекле җәза уза.* И.Сиражи

**ТӘҮЛЕКЛЕК** *с.* 1) Бер тәүлек эчендә башкарыла, эшләнә, яшәлә торган. *– Бездә тәүлеклек ясле-бакча эшли, – диде.* М.Маликова. *Бүген бер сыердан тәүлеклек савым 24 килограммга җитә.* Кызыл таң

2) Саннар белән килгәндә, шул сан белән күрсәтелгән тәүлек эчендә була, дәвам итә, сузыла торган. *Чирле икәнен белә торып, хатыныңны өч тәүлеклек юлга алып чыккансың.* А.Гыйләҗев. *Биш тәүлеклек сабый агасы кулында җилкенеп чапканын да аңлыйдыр шикелле.* Р.Батулла

**ТӘҮМӘЛ** *и. диал.* Вакытның билгеле бер өлеше, күпмедер вакыт, ара. *Бер тәүмәлгә туктап тору*

**ТӘҮМӘЛЕ** *бәйл.* Чаклы, хәтле, зурлыгы, кадәрле. *Хуҗа хатыны – мич тәүмәле буйчан һәм юан бер апа.* А.Расих. *Өй тәүмәле бу сәер машиналар инде безнең турга җитеп килә.* М.Галиев

**ТӘҮМӘЛЕГЕ** *бәйл. к.* **тәүмәле**. *Тау итәкләрендә, тар гына тигезлекләрдә, юл буйларында каяндыр өстән, кыя башларыннан кителеп төшкән өй тәүмәлеге ташлар тәгәрәшеп ята.* Н.Фәттах. *Ә Галәмдә, Галлей кометасы тәүмәлеге булып, зур сорау билгесе очып бара: – Исеңдәме?! – ди.* М.Вәлиев

**ТӘҮРАТ** *и. гар.* Библиянең бер өлеше; Муса пәйгамбәргә бирелгән, яһүдилекнең төп тәгълиматын үз эченә алган изге китап; *русчасы*: **Тора**. *Тәүрат, Библия, Коръән кебек изге китаплар кешене бары тик яхшылыкка гына өнди.* Ф.Хуҗин. *Тәүрат башта ташка чокып*

*язылган, аннары бозау тиреләренә, ахырда кәгазь битләренә күчерелгән, диләр.* А.Тимергалин

**ТӘҮСЫЯ** *и. гар. иск.* 1) Берәр нәрсәне эшләү-эшләмәүгә үгетләү, шул хосуста юл күрсәтү. *Табиб тәүсыясе*

2) Киңәш, тәкъдим

3) Үтенеч; васыять. *Тәүсыя әйтеп китү*

**ТӘҮСЫ́Я ИТҮ** *ф. иск.* 1) Үгетләү, нәсыйхәт бирү

2) Киңәш итү; рекомендация бирү. *Мәшәкать дигән, тынычсызлану дигән нәрсәләрне хәтерегезгә дә китермичә калуыгызны тәүсия итәр идем.* Ә.Фәйзи

3) Васыять итү

**ТӘҮФИКЪ** *и. гар.* 1) *дини* Нәрсә дә булса эшли алу өчен Аллаһның ярдәме, Аллаһның нәрсәгә дә булса юл ачуы. *Аллаһы Тәгаләдән тәүфикъ вә һидаять ирешкән кеше гыйлем вә вәгазь мәҗлесеннән тәүбә вә истигъфар белән кайтадыр.* К.Насыйри

2) Әдәплелек, тәрбиялелек, тыйнаклык, күркәм әхлак. *Ну, Лотфулла энекәш, тәүфикъ дигән нәрсә юк инде синдә, ә?* А.Хәлим. *Син йоклап киткәч, керфек какмыйча, сиңа тәүфикъ тели идем.* Г.Сабитов

◊ **Тәүфикъка килү** *к.* **тәүфикъ табу**. *Ире сабырланыр, тәүфикъка килер дип уйлады.* Х.Ибраһим. *Уйлансыннар, тәүфикъка килсеннәр, хакыйкатькә кайтсыннар, дигәндер.* Г.Гыйльманов. **Тәүфикъка утырту** Яхшы юлга бастыру, яман гадәтләрдән биздерү. *Бәлки, менә минем ише карак малайларны тәүфикъка утыртып булмасмы, халыкның азрак аңын күтәрә алмаммы дип, шулай базардан базарга чана сөйрәп, бер тиенсезгә азапланып йөри торгандыр әле.* Г.Бәширов. **Тәүфикъка утыру** *к.* **тәүфикъ табу**. *Ничә әйтсәң дә бер сүз: тәүфикъка утырды Мөнәвәр карт, культурный балалар кайткач.* Ф.Хөсни. **Тәүфикъ табу** Начарлыкка бирелеп тә, соңыннан тыелу, тыйнаклану, әдәпләләнү; тәүфикълану. *--- тәүфикъсызларга тәүфикъ табарга булыш, юлдан язганнарга юл күрсәт, мескеннәргә, кеше кулына карап тилмереп ятучыларга саулык иңдерә күр!* З.Хөснияр. *Яхъя пәйгамбәрне төштә күрүне бу китапта дин һәм әдәп, тәүфикъ табарсың дип юрарга өйрәтелә.* Ф.Яхин

**ТӘҮФИКЪЛАНУ** *ф.* Тәүфикълыга әйләнү, тәүфикълы булып китү. *Качан тәүфикъландың болай, Сәдрү?* Һ.Такташ. *Тәүфикъланды, песи кебек хәзер, мескен ---.* Ф.Яхин

**Тәүфикълана бару** Акрынлап, азазлап тәүфикълану. *Егет тәүфикълана бара*

**Тәүфикълана башлау** Тәүфикълануга табан бару. *Соңгы айларда тәүфикълана башлаган энесеннән мондый сүзләр көтмәгән иде ул.* Туган як

**Тәүфикълана төшү** Бераз, бернигадәр тәүфикълану. *Малайларның олысы чынлап та тәүфикълана төште.* Сәхнә

**Тәүфикъланып бетү** Тәмам тәүфикълану. *– Болай булса, бөтенләй тәүфикъланып бетәсең бит инде, яулык бәйлисе генә кала, – дип көлеп калды иптәш кызы.* Р.Вәлиева

**Тәүфикъланып калу** Билгеле бер сәбәптән, хәлдән, вакыйгадан соң тәүфикълану, тәүфикълы булып күренү. *Азгыннар да тәүфикъланып кала. Рәт беткәч.* Ш.Галиев

**Тәүфикъланып килү** Тәүфикълана башлау, бераз тәүфикълану. *Мәчетмәдрәсә юлына баскан улының тәүфикъланып килүен күрү ата-ана өчен зур сөенеч иде.* Мәдәни җомга

**Тәүфикъланып китү** Сизелерлек, күзгә күренеп тәүфикълану. *Гөлбануның атасы Нурый карт, яшь чагында ярлы һәм тәүфикъсыз булып, урлау-талау кебек эшләрдә генә йөрсә дә, тапкан берсен эчеп бетерә барса да, өлкәнәя төшкәч баеп һәм тәүфикъланып киткән иде.* Г.Ибраһимов. *Соңгы көннәрдә әти тәүфикъланып китте әле. Төннәр буе яза, сөйләшми, тартмый.* М.Хәбибуллин

**ТӘҮФИКЪЛЫ** *с.* Әдәпле, тәрбияле, тыйнак, күркәм әхлаклы. *Тирә-якның бер матуры булып үскән бу малай бик тәүфикълы һәм уңган икән, ләкин бөкре булуы аркасында гына кеше арасына чыкмый яши, ди.* Г.Гыйльманов. *Аллага шөкер, игелекле, тәүфикълы булып үсте Азаматлары.* А.Әхмәтгалиева

**ТӘҮФИКЪЛЫЛЫК** *и.* Тәүфикълы булу сыйфаты. *Тәүфикълылык исә адәм баласына ата-ана тәрбиясе белән керәдер.* М.Хәбибуллин. *Аны бетерү, аңа шәфкатьлелек, тәүфикълылык нурын даими өстәп тору вазифасы инде сиңа йөкләтелә.* С.Поварисов

**ТӘҮФИКЪСЫЗ** *с.* Әдәпсез, тәрбиясез, азгын, бозык әхлаклы; тыйнаксыз, тотнаксыз. *Дәүләт дисәң, тәүфикъсыз бай балаларына дәүләт бетерү бернәрсә түгел.* Г.Исхакый. *Малаемны бозар инде бу тәүфикъсыз нәрсә, дип уйлагансыңдыр.* А.Алиш

**ТӘҮФИКЪСЫЗЛАНУ** *ф.* Әхлаксызлану, тәүфикъсызлык күрсәтү, тәүфикъсызга әйләнү. *Ул арада Мәдинә, әллә нинди мәзәк-сәер тавышлар белән шаркылдап көлеп чалкан ятты да, тәүфикъсызланып, тәкатьсезләнеп, Галимҗанны янына чакырды ---.* С.Поварисов. *Аннары, шаярту катыш, шәһәр кызларына бик ияләшә-нитә китеп тәүфикъсызланма, дигәнсең.* Н.Хәсәнов

**Тәүфикъсызлана бару** Акрынлап, аз-азлап тәүфикъсызлану. *Күреп торасыз: яшьләр елдан-ел тәүфикъсызлана бара ---.* Ш.Маннур

**Тәүфикъсызлана башлау** Тәүфикъсызлануга табан бару. *Тәүфикъсызлана башлаганчы башлы-күзле итеп, урнаштырып калуың хәерлерәк.* Ф.Хөсни

**Тәүфикъсызланып бетү** Тәмам тәүфикъсызлану, бөтенләй тәүфикъсызлану. *Яшьләр тәүфикъсызланып бетмәсен дисәк, бар көчебезгә тырышырга тиешбез.* Мәйдан

**Тәүфикъсызланып йөрү** Озак вакытлар тәүфикъсызлану. *Тәүфикъсызланып йөрергә вакыты булмады аның, ничә ел өч җирдә эшләде.* Р.Камал

**Тәүфикъсызланып китү** Соңгы вакытта тәүфикъсызлану

**ТӘҮФИКЪСЫЗЛЫК** *и.* Әхлаксызлык, әдәпсезлек, тәрбиясезлек. *«Тәүфикъсызлык чигенә җитеп», мин тәмәке дә тарта башлыйм.* Г.Камал. *Бабалары исә аптырашта ук калып, бераздан гына телгә килә алды: «Әнкә рухын рәнҗетү – тәүфикъсызлык».* Ә.Баян

**ТӘҮХИД** *и. гар. дини* Берилаһлык, монотеизм. *Тәүхид гыйлеме Аллаһы Тәгаләнең бер вә барлыгын тану аша*

*аның белән генә яшәү рәвешен, ягъни Хак Тәгалә әмере белән генә ахирәткә фикер куеп яшәү рәвешен бәян итә.* Ф.Яхин

**ТӘФ** *иярт.* Нечкә генә тавыш белән өзек-өзек итеп эт өргәндә чыккан авазны белдерә. *Бу көчек тә бик гайрәтле күренә. «Яшен» чыга башлаганнан бирле, безнең «Яшен» капка төбендә «Тәф!»* Г.Камал. *Ул урамда өргән этләр артыннан кабатлап куйды: «Тәф!»* Кызыл таң

**ТӘФКЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Нечкә тавыш белән өзек-өзек өрү, өргәләү (кечкенә эт яки төлке тур.). *Читтә тәфкелдәп утырган эт балтырдан килеп эләктермәсен.* К.Тинчурин

2) *күч.* Юк-бар сәбәп табып кемне дә булса тиргәү, сүгү. – *Тәфкелдәргә ярата инде ул шулай, игътибар итмә, – диде дә, кулын селкеп, тиз-тиз атлап китеп барды.* Р.Вәлиева

**Тәфкелдәп куюю** Кинәт бер мәртәбә тәфкелдәү. *Ниндидер бер эт тәфкелдәп куйгач кына, алар карашларын каршы як ярга төбәделәр һәм елга кырыендагы чуерташлы ком өстеннән арлы-бирле йөрүче кешене күрделәр.* Я.Шәфыйков

**Тәфкелдәп тору** Әле, хәзер тәфкелдәү; гел тәфкелдәү. *Бертуктамый тәфкелдәп торган этен тизрәк алып китәргә ашыкты кыз.* Ялкын

**Тәфкелди башлау** Тәфкелдәргә тотыну. *Урамда этләр тәфкелди башлады*

**ТӘФСИЛ** *и. гар.* 1) Берәр нәрсәнең бөтен нечкәлекләренә, ваклыкларына кадәр җентекле аңлатмасы. *Инде монда артык тәфсил хаҗәт түгел.* К.Насыйри. *Тарих белән шөгыльләнгән затлар бу җирдә кыскартып язган нәрсәләрне беркадәр тәфсил белән һәм бу хәлләрнең мәйдан алганына сәбәпләрен күрсәтеп язарга теләсәләр, шәкертләр файдалануына лаеклы булачак бер әсәр булыр иде.* Туган як

2) Сөйләнгән, тасвирланган нәрсәнең вак детале; нечкәлек, ваклык. *И угыл, һәр сүзне тәфсил белән сөйләсәм, озак булыр.* К.Насыйри. *[Нәгыймь] тигез тавыш, салкын кан белән, әкият сөйләгән төсле, вак-төяк тәфсилләре белән тезеп кенә тора.* Ш.Камал

**ТӘФСИ́Л ИТҮ** *ф.* Тәфсилләү. *Китәсе көнне бу минем белән бигрәк артык якын да, дуст та кебек кыйланган булып, үзенең «милләт» юлындагы күп хезмәтләрен санады, дошманнарыннан зарланды, үзе турында «...» газитәсендә ялганлап, яманлап язганлыкларын тәфсил итә башлады.* Г.Салихов. *Язмышының катмарлы, гыйбрәтле булуы да өченче зат тарафыннан гына тәфсил ителә.* Шәһри Казан

**ТӘФСИ́Л КЫЛУ** *ф. к.* **тәфсил итү**. *Хуҗаның соравын да көтмичә, гыжлый-гыжлый, Макар үзе барысын тәфсил кылды: – Анда яшәгән вотяклар, чирмеш вә болгарлар янына Новгородтан качкан урыслар да барып кушылганнар.* В.Имамов

**ТӘФСИЛЛӘ́Ү** *ф.* Тулысынча, җентекләп, бәйнә-бәйнә аңлату. *Ул елларда күргән-кичергәннәрен тәфсилли китсәң, кәгазь җитмәс.* К.Тимбикова. – *Минем яңа тарханнарым өчен нинди ташламалар каралган, аларын да тәфсилләә, – дип, Мөхәммәдәмин янә яралларына тоз сипте.* М.Әмирханов

**Тәфсилләп бирү** Кем өчендер тәфсилләү. *Борынгы бабаларыбызның мирасын хәзерге татар теленә шагыйрь Әхмәт Гадел тәфсилләп бирә.* М.Хәбибуллин. – *Горизонттан югалып тор, җир тишегенә кер, яфрак астына сыен, – дип, полковник иренмичә аңлатып, тәфсилләп бирә.* Т.Галиуллин

**Тәфсилләп тору** Озак тәфсилләү; сөйләү моментында тәфсилләү. *Милләтпәрвәрләребез мине аңлар, шуңа күрә шәхси шатлык-куанычларыбызны тәфсилләп торуны кирәксенмим.* А.Тимергалин. *Ул көнне тагынниләр сөйләшүебезне тәфсилләп торуның кирәге юктыр, туган.* В.Нуруллин

**Тәфсилли башлау** Тәфсилләргә тотыну. *Аның тормыш юлын тәфсилли башласаң, китап язарлык.* Зәй офыклары

**ТӘФСИЛЛЕ** *с.* **1.** Җентекле, озын, нечкә тасвирлы. *Мин бу хакта прокуратурага да, башка урыннарга да тәфсилле мәгълүматлар җибәрдем.* Ф.Фәтхи. *Болар хакында тәфсилле сүзне сөйләргә яраткан Зарифулла хәзрәтнең абыстае Хафизаттәй ашка чакырулы иде.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Җентекләп, бөтен ваклыкларына, нечкәлекләренә кадәр аңлатып. *Нәҗми, язучылар оешмасы рәисе буларак, татар әдәбиятының шул чордагы торышы турында тәфсилле сөйли ---.* Р.Фәйзуллин. – *Хәзер тыңла, – дип, Сәет кайчан, кемне әтмәлләргә кирәклеге турында бик тәфсилле сөйләде.* Т.Галиуллин

**ТӘФСИР** *и. гар. дини* 1) Коръәннең аятьләрен аңлату, мәгънәләрен киңәйтеп ачыклап язу. *Дөрес, бер укуда ук аңлашыла торган аятьләр дә байтак, ләкин Коръәне Кәримнең махсус аңлату, тәфсир кирәк булган урыннары да җитәрлек.* Р.Батулла

2) Ислам илаһиятында Коръән аятьләренең аңлатмаларын, мәгънәләрен өйрәнә торган фән. *Төрле фәннәрдән – фикъһедән, тәфсирдән, тыйбтан вә голүм гарәбиядән дәрес укыды.* К.Насыйри

3) Коръән сүрәләренә аңлатма биргән әсәр. *Коръән өлеше гарәп имласы белән гарәп телендә, тәфсир өлеше латин имласында госманлы яки төрек-ислам телендә бирелә.* И.Әмирхан

**ТӘФСИ́Р ИТҮ** *ф. к.* **тәфсир кылу**. *Сөйләгән сүзләре, мохакәмә (фикер) йөртүе, хәзрәте Гайсәнең могҗизаларын фән ягыннан тәфсир итәргә тырышуы – бу кешенең Аурупа тәрбиясе күргән икәнен күрсәтә иде.* Х.Миңнегулов

**ТӘФСИ́Р КЫЛУ** *ф.* Коръән аятьләрен аңлату, ачыклау. *Мәсәлән, Коръәнне урысчага тәфсир кылган Иман Валерия Порохова да шундый карашта икән.* Р.Сафин. *Татар галимнәре татар халкын мәңгелек галәми милләт итәселәре килсә, --- ягъни Коръәне Кәримне шушы фән телендә тәфсир кылсыннар иде.* И.Әмирхан

**ТӘФСИРЛӘҮ** *ф. к.* **тәфсир кылу**. *Бу очракта, күрәсең, моңарчы җиткерелгән Изге Китапларны бозу сәбәпләре дә искә алынгандыр, чөнки эчтәлеге ачык һәм гавам өчен аңлаешлы булган аятьне шайтани ниятә тәфсирләү авырая.* Р.Сафин. *Коръәнне дүрт редакциясендә белә, сүрәләрне яттан сөйли, тәфсирли торган абыстай.* Г.Шәйхи

**Тәфсирләп бирү** Кем өчендер тәфсирләү. *Ә менә ислам тәгълиматының асылын дөньяви күзлектән аңлатып, тәфсирләп бирә алучы бармы?* Безнең гәҗит

**Тәфсирләп чыгу** Барысын да тәфсирләү, башыннан ахырына кадәр тәфсирләү. *Аятьләрне тәфсирләп чыкты*

**ТӘФСИРЧЕ** *и.* Коръән аятьләрен аңлатучы галим, тәфсир авторы, мөфәссир. *Тәфсирчеләр язуынча, «өч хәрефтән торган ошбу кыска аятьнең мәгънәсен әйтүче юк».* Р.Сафин. *Мин тәфсирче түгел, мин – тәрҗемәче. Дистәдән артык Коръән тәфсире ярдәмендә шул тәфсирләрнең тәрҗемәсен генә эшләдем.* Мәдәни җомга

**ТӘФ-ТӘ́Ф ИТҮ** *ф.* 1) Нечкә генә тавыш белән өзек-өзек өрү. *Боларның бу тынычлыклары озакка бармады, кинәттән бер капка астыннан кечкенә генә курнос көчек тәф, тәф иткәч тә, аның артыннан икенчесе, аннан өченчесе, дүртенче, бишенче, алтынчы. Күз ачып күз йомганчы, иллеләп этләр җыелып та калды.* Г.Тукай. *Хәзер тәф-тәф итеп өреп килгән Муйнакны күрүгә, беренче булып ул кача башлый.* Т.Мөбарәков

2) *күч.* Өзек-өзек нечкә генә тавыш чыгару. *Каяндыр тәф-тәф иткән тавыш чыкты*

**ТӘФТИШ** *и. гар. кит.* 1) Берәр нәрсә, эш, объект турында сорашып, сынап, күзәтеп, кирәкле мәгълүмат алырга тырышу; махсус рәсми тикшеренү үткәрү. *Хәкимнәре һәрберсе бер төрле сүз әйтеп, бәгъзылары җен эше дип вә бәгъзылары дәхи китап карап, гыйлем куәте белән җирне-күкне сәер кыйлып, тәфтишкә тотындылар.* К.Насыйри. *--- тәфтиш материаллары арасында мулла Морад язмаларыннан алынган аерым өзекләрнең русчага тәрҗемәләре сакланып калган.* Мәдәни җомга

2) Берәр мәсьәләне тикшергән фәнни хезмәт; фәнни тикшеренү. *Менә, җыеп әйткәндә, Каюм Насыйриның Казан татарларының халык әдәбиятын җыю һәм тәфтиш юлында эшләгән хезмәтләре шулардан гыйбарәт.* Х.Габделбәдигъ. *Бай эчтәлекле, мәгънәле «Идел» журналының искергән, кулланылыштан чыккан сүзләрне тергезергә омтылуы да аңлашылып бетми: --- тәфтиш (фәнни тикшеренү); гамил (фактор); мөәррих (тарихчылар); фикер хаяты (идеология); һөнәрмәнд (профессионал).* Р.Юсупов

3) Берәр оешманың яки хезмәткәрнең эшен тикшерү; эшнең дөрес алып барылу-барылмавын ачыклау, бәяләү; ревизия. *Көн яктыргач, станциядән жандармнар килеп тәфтиш ясадылар.* Ш.Камал. *Тәфтиш комиссиясе Фәтхулла хәзрәт өендәге кәгазьләр арасында киләчәктә шушындый хәлләр килеп чыккан тәкъдирдә нишләргә кирәклеген тәфсилләп күрсәткән язмалар һәм программ дискеталар да тапты.* А.Тимергалин

4) Җинаять эшен тикшерү. *Шуннан соң ул, тәфсилле һәм тагы да шомлырак итеп, Маһруйның ничек Ягъкубны үтерүен һәм бу җинаятьне тәфтиш вакытында аның тикшерүчегә сөйләгән сүзләрен, --- һәммәсен сөйләп бирде.* З.Бигиев

5) Тентү, нәрсә дә булса эзләп табу максаты белән тикшерү. *Русия буйлап туктаусыз алып барылган тентү, тәфтиш, кулга алулар ише «фетнәле эшләрнең» башы, чыннан да, кайда?* Р.Зарипов

**ТӘФТИ́Ш ИТҮ** *ф. кит. к.* **тикшерү** (*1–4 мәгъ.*). *Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: сез дәхи, ул падишаһ кебек тәфтиш итеп, вәзирләр сүзе белән гамәл итәсез, вә шәригатькә ияреп гомер итәсез ---.* К.Насыйри. *Мәсәлән: «Арыслан, әлбәттә, Бүренең кан эчкүче залимлеген күп ишеткән булырга кирәк: тиз генә Бүрегә бу вазифаны бирмәскә теләп тәфтиш итмәс өчен, Юлбарыс, Кәркәдән, Фил, Кабан дуңгызы кебиләрне каршына чакырып: «Сез Бүрене ничек дип беләсез?» – дип сорашты».* Г.Гыйльманов

**ТӘФТИ́Ш КЫЛУ** *ф. к.* **тәфтиш итү**. *Ни вакыйга бар, дип тәфтиш кыйлып карадым, сораштым.* К.Насыйри. *Бай, берничә алтын намунәләрне алып, кислоталарга салып һәм төрле дарулар тиереп карап, алтынның чынмы, ялганмы идекене тәфтиш кыйлып карады.* Г.Камал

**ТӘФТИШЛӘ́Ү** *ф. кит. к.* **тикшерү** (*1–4 мәгъ.*). *Мөхәррир тәфтишли һәр язганны, Уздырмаска теләп хилаф сүз ---.* Р.Зарипов

**Тәфтишләп бару** Рәттән, эзлекле рәвештә тәфтишләү. *Без язганны тәфтишләп бара ул*

**Тәфтишләп бетерү** Тәфтишләүне тәгәлләү, тулысынча тәфтишләү. *Текстны тәфтишләп бетергәнче, бер сүз дә дәшмәде ул ---.* Мирас

**Тәфтишләп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле тәфтишләү; озак вакыт дәвамында тәфтишләү. *Кадрлар бүлегендә артык тәфтишләп тормадылар.* Җ.Дәрзаман. *Туганлык, гаилә мөнәсәбәтләренә бик сизгер булган, гаять күзәтүчән, нечкә психолог Фатих Әмирханның да үз нәселен, даирәсен тәфтишләп торганы билгеле.* Р.Әмирхан

**Тәфтишләп утыру** *к.* **тәфтишләп тору**. *Шәкертләрнең һәр адымын тикшереп, тәфтишләп утыра торган гадәте юк иде аның.* Г.Мөхәммәдова

**Тәфтишләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм, берсе артыннан берсен тәфтишләү, барысын да тәфтишләү. *Шулай ук шагыйрьнең башлангыч иҗатына караган күп кенә шигырьләрен дә, тәгаенрәк әйткәндә, аларның хәзерге әдәби телгә күчермәләрен дә яңадан тәфтишләп чыгарга кирәк.* Мәдәни җомга

**Тәфтишли башлау** Тәфтишләргә тотыну. *Хәер, аның ул монографиясен бүгенге шартлардан, мөмкинлекләрдән чыгып тәфтишли башласак, билгеле инде, анда безнең заманга муафикъ булмаган кимчелекләр дә күрербез, бүгенге көн күзлегеннән караганда дөрес үк күренмәгән фикерләр белән очрашырбыз.* З.Рәмиев

**ТӘФТИШЛЕ** *с.* Җентекле, бөтен ваклыкларына кадәр эшләнгән. *Бу бүлекчә Дәрдемәнд мирасын, шагыйрьнең вафатыннан соң, тәфтишле, эзлекле һәм төрле яклап өйрәнүдә беренче һәм, әйтергә кирәк, уңышлы хезмәт.* Ф.Галиуллин

**ТӘФТИШЧЕ** *и.* 1) *к.* **тикшерүче** (*2 мәгъ.*). *Күпчелекне гарәп-фарсы алынмаларыннан татар телендә ясалган неологизмнар тәшкил итә: гамәлче, иминиятче, икътисадчы, иттифакчы, сәнәгатьче, тәфтишче, фиркачы, хәйрияче, химаяче.* Р.Мөхиярова. *Тәүдә оперуполномоченный, ары таба тәфтишче, янә бер елдан тикшерү бүлеге җитәкчесе, 1967 елда исә аны Шаран районының милиция бүлеге начальнигы итеп тәгаенлиләр.* Кызыл таң

2) Ревизор. – *Разберёмся! – диде эре генә итеп тәфтишче.* З.Мурсиев. *Ләкин тәфтишче бер-ике сәгать узгач кына килде.* Туган як

**ТӘХӘЛЛҮС** *и. гар.* 1) *к.* **нисбә**

2) Псевдоним. *Тәхәллүсне олыдан, истә калырлык итеп бирәләр.* Т.Галиуллин. *Аңа әдәби тәхәллүсне дә (псевдоним) поэзиябезнең аксакалы Хәсән ага Туфан бирә.* Т.Нәҗмиев

**ТӘХЕТ** *и. фар.* 1) Рәсми кабул итү мәҗлесләрендә һәм башка тантаналарда патша утырыр өчен калкурак урынга куелган, кыйммәтле ташлар, алтын һ.б. белән бизәлгән зиннәтле урындык. *Пәрдә артында алтын һәм җәүһәрдән ясалган тәхет өстендә патша күренде.* К.Насыйри. *Алай да тәвәккәлләде: көннәрдән бер көнне туп-туры Йосыф кахан утырган тәхет ягына килеп керде.* М.Хәбибуллин

2) Хөкемдарлык; патша дәрәҗәсе; власть. *Ул безгә ап-ачык итеп белдерде: – Мин агамны үземнән өстен саныйм, тәхеттән баш тартам, – диде.* Н.Фәттах. --- *аның тәхеттән китүе сәясәттә күп үзгәрешләргә китерәчәген аңлыйлар.* Г.Галәметдин

3) Җитәкчелек урыны, вазифасы; хакимлек итү, башкалардан өстен булу мөмкинлеге. *Кан күргәч әсәренгән үгезләр кебек, бер-берсен таптарга җитешеп, Политбюро әгъзалары борынгыдан ук кеше аңын иләсләндереп килгән майлы калҗа: власть, хакими тәхет бүлешәләр.* Ш.Галиев. *Ә тәхет белән бәйләнешле шәхесләр тирәсендә бервакытта да ыгы-зыгы, гайбәт бетеп тормый.* М.Әмирханов

◊ **Тәхеткә menү** Дәүләт башлыгы булып идарә итә башлау. *Бер елдан соң Александр II үтерелә, аның урынына Александр III тәхеткә менә.* А.Тимергалин. **Тәхеткә утыру** *к.* **тәхеткә менү**. *Ә низагның сәбәбе – Бөек Русь тәхете варисларының кенәз Владимирдан (Красное Солнышко) калган тәхеткә утыру тәртибен бозу, дип саныйлар тарихчылар.* И.Хуҗин. **Тәхет кылу** *кит.* Кемне дә булса шатландыру, күңелен табу. *Тәхет кыл кырмысканың күңелен – Сөләйманлык будыр!* Дәрдемәнд. **Тәхеттән төшерелү** Хакимлек итүдән, идарә итүдән туктатылу, вазифасыннан азат ителү. *Кичәге түрәләр инде мотлакый авторитет түгел, күбәүләр «тәхеттән төшерелде», кара ягылган зыялы милләттәшләребез акланды һәм реабилитацияләнде.* А.Тимергалин. *Кыскасы, илдә низаглар башланды, һәм алар минем тәхеттән төшерелүем белән тәмамландылар.* И.Хуҗин. **Тәхеттән төшерү** Хакимлектән алу, идарә вазифасыннан азат итү. *Алтан ханны тәхеттән төшереп, җирләрен кул астына алганнан соң, мин чин-кытайлардан унсигез белгеч-галим чакырттым.* М.Галиев. **Тәхеттән төшү** 1) Дәүләт башлыгы булудан, идарә итүдән, хакимлек итүдән, дәрәҗәле вазифа башкарудан туктау. *Дөрес, тәхеттән төшкән түрәне типкәләү дә бик миһербанлы эш түгелдер.* Р.Батулла; 2) Җылы урыннан колак кагу; дәрәҗәсе төшү, абруе кимү. *Безнең түрәләр тәхеттән төшеп калудан куркалар, шуның өчен, халыкка яхшылык эшләмәсәләр дә, Мәскәүгә яраклашу өчен, барлык көчләрен куячаклар.* Безнең гәҗит. **Тәхет тоту** Дәүләт башлыгы буларак идарә итү, хөкем иясе булу. *Хәер, бабаң, атаң, бөтен егерме буынлык нәсел-ыруың тәхет тотсын да, ничек ханлык каныңа сеңмәсен, ди.* М.Әмирханов. *Дәүләтеңдә татар ханы Тәхет тотмас инде бүтән: Бәйсезлеге китә илнең Синең белән, Сөембикәм.* Т.Кәримов

**ТӘХЕТЛЕ** *к.* 1) Монархияле, үзендә монархия булган (ил). *Тәхетле ил сәясәте*

2) Дәүләтле. --- *Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән дәүләтле-тәхетле булырсың, пәйгамбәрлек-нәбилек дәрәҗәләренә ирешерсең, Мәшрикъ һәм Мәгъриб олугларына танылырсың, дип күрәзәчелек итүе «Кыйссаи Йосыф» китабының сюжет көпчәген гаугалы конфликтка әверелдереп җибәрә.* Р.Ганиева

3) Хокуклары, вазифалары, мөмкинлекләре һ.б.ш. белән башкалардан өстен; дәрәҗәле, статуслы; башкалар санлаша, хөрмәт итә торган. *Тәхетле башкалаларга менә шул салымнарның искиткеч зур күләмдә җыелуы зур шәһәрләрнең барлыкка килүенә бер этәргеч бирә.* Р.Мөхәммәтдинов. *Тынгы тапмас беркем мондый илдә, Булган очракта да тәхетле.* Р.Мөхияр

4) Бар яктан да әйбәт, канәгатьләнерлек, яхшы (тормыш шартлары, яшәү, халәт һ.б.ш. тур.). *Тормышымның иң бәхетле көне, Иң тәхетле көне – бүгенем.* Э.Шәрифуллина

**ТӘХЕТЛЕК** *и. сир.* 1) Патша хакимияте; патша дәрәҗәсе. *Тәхетлеге дошманына калды, шуңа кара янган ул.* Әкият

2) Иң өстен, иң югары, дәрәҗәле булу сыйфаты. *Имәннән хәзер тәхетлек шәрәфе дә китә.* Ш.Әхмәдиев

**ТӘХИЯТ** *и. дини к.* **әттәхият**

**ТӘХКЫЙК** *и. гар. иск.* **1.** Фәнни раслама, фәнни хакыйкать. *Барлык тәхкыйкларга да игътибар итәргә кирәк, дип өйрәттеләр.* Гасырлар авазы

**2.** *кер. сүз функ.* Дөрестән дә, чынлап. *Тәхкыйк, үзеңне үз кулың белән һәлак кыйлдың.* К.Насыйри

**3.** *рәв. мәгъ.* Ачык, шиксез. *Хәлвәфрүш тәхкыйк белде: бу дәрвишнең кулыннан килә торган эш юктыр.* К.Насыйри

**ТӘХКЫ́ЙК ИТҮ** *ф.* Дөреслегенә төшенергә тырышу, дөреслеген, чынын белү. *Ләкин тугрысын тәхкыйк итә алмадым.* Г.Камал

**ТӘХКЫ́ЙК КЫЛУ** *ф. к.* **тәхкыйк итү**. *Һәр кеше эшен ташлап, моның сәбәбен тәхкыйк кыйлып белделәр: барысы Әбүгалисина эшедер.* К.Насыйри

**ТӘХКЫ́ЙРАНӘ** *рәв.* **1.** Хурлап, мыскыллап, кимсетеп, түбәнсетеп. *Шуннан соң хан яңадан Мәскәүгә илчеләр җибәреп, Казан вә Әстерханны һәм бик күп бүләкләр бирүне таләп кылды, ләкин Мәскәү хөкүмәте моңарга тәхкыйранә җавап кайтарды.* Г.Гобәйдуллин. *Йолдыз бала аларның киңәшенә, вәгазенә колак салмый, әһәмият бирмичә тора да, тагын алардан тәхкыйранә көлеп, үз иптәшләре янына барып хөкем сөрергә тотына иде.* Н.Әхмәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Хурлау белән тулы, мыскыллы. *Тәхкыйранә карашыгызны, керле йөрәгегезне күреп тә, ничек мин сезгә ышаныйм?!* Ш.Әхмәдиев

**ТӘХКЫЙРЬ** *и. гар. иск.* Намуска тию, кимсетү, мыскыл, хәкарәт.

*Фәкать муллалар сценасы, кирәгеннән артык көлү илә мәзах вә һөҗүдән чыгып, тәхкыйрь дәрәҗәсенә килеп җитеп, хикәяне бераз тозсызландырып җибәрмештер.* Г.Камал. --- *Мин... мин бу тәхкыйрьне онытачак түгелмен.* Ә.Еники

**ТӘХКЫ́ЙРЬ ИТҮ** *ф. кит.* Хурлау, мыскыллау, кимсетү; намуска, күңелгә тиярлек сүз әйтү яки эш эшләү. *Болай каравыгыз мине тәхкыйрь итә.* Г.Ибраһимов. *Менә профессор әфәнде, шаһит булыгыз, менә бу шифырт хәлфә кисәге мине, ахмак, психопат, дип тәхкыйрь итте.* К.Тинчурин

**ТӘХКЫ́ЙРЬ КЫЛУ** *ф. кит. к.* **тәхкыйрь итү**. *Мине тәхкыйрь кыласың!* Г.Ибраһимов. *Җиһанда кырык алты ел гомер кичереп тә кыз яугирләрнең кылыч, җәя белән ир баһадирларны хәрабә вә тәхкыйрь кылганына һич инанмас идем.* Р.Батулла

◊ **Тәхкыйрь күзе белән карау** Кемгә дә булса кимсетүле, мыскыллы мөнәсәбәт күрсәтү. *Беренче танышуда ук Рокыя Габдулладан бөтенләй бизә, аңа тәхкыйрь күзе белән карый башлый.* Ш.Әхмәдиев. *Теге егет, аның башыннан аягына кадәр бер тәхкыйрь күзе белән карап: – Баш мөхәррир?* Гали Рәхим

**ТӘХКЫЙРЬЛӘ́Ү** *ф. кит. к.* **тәхкыйрь итү**. *Ниндидер тупас хайваннар аңсыздан басып керәләр дә тәхкыйрьләп чыгып китәләр.* Г.Ибраһимов. *Минем бу чишмәне тәрбия кылуым күңеленә җарамый адәмнең, ул «Убыр чишмәсе» дип тәхкыйрьли.* Н.Гыйматдинова

**ТӘХКЫЙРЬЛЕ** *с.* Кимсетүле, мыскыллы, мәсхәрәле, хәкарәтле. *Каравыл солдатлар, яшь офицерлар алдында мондый тәхкыйрьле сүгенүләрне ишетү прокурор өчен бик авыр булып төште.* Г.Ибраһимов. *И-и, менә нинди тәхкыйрьле халәттә синең илә очрашырга туры килде, яшьтәш.* В.Имамов

**ТӘХЛИЛ** *и. гар. дини* Шәригатькә күрә ире өч талак белән аерган хатынның, башта икенче бер иргә никахланып, аңардан да аерылып яки тол калганнан соң, кабат беренче иренә никахлашуы. *Син бит ул сүзне өч тапкыр әйткәнсең, «мең тапкыр...» дип тә кычкыргансың әле, шулай булгач, хәзер тәхлил кирәк инде...* М.Галәү. *Әгәр дә өч талак хөкеме төшкәннән соң тәхлил кылынса (талак гафу ителсә), яңадан ул ир бу хатынына өйләнсә, тагын шул йортка керсә, араларына талак хөкеме башка төшмәс.* Ф.Яхин

**ТӘХМИН** *и. гар. иск.* Нәрсәне дә булса чамалап, якынча, шулай дип уйлап әйтү, эшләү; чама. *Вафат тарихлары табылмаган затларны тәхмин берлә генә бер урынга куйдык.* Гасырлар авазы

**ТӘХМИ́Н ИТҮ** *ф. иск.* Чамалау, якынча гына билгеләү. *Шул хисапларга караганда, сугыш өчен тотылган акча расходы түбәндәгечә тәхмин ителәдер.* Г.Исхакый. *Бу җирләрнең елына ничә йөз мең сумнар файда китерәчәген тәхмин итәләр.* Г.Камал

**ТӘХМИ́Н КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәхмин итү**. *Моннан соң татарны мин кем дип тә тәхмин кыла алмый башладым: сөйләшүе, кыланышы, хәтта күз карашы бөтенләй зыялыларча; киеме бөтенләй иске татарларча.* Ф.Әмирхан

**ТӘХРИР** *и. гар. иск.* 1) Берәр төрле язу; язылган, теркәлгән нәрсә, язма эш; басылып чыккан текст. --- *ул мөхәррир кәгазьне янә куенына салганда, солтан Мөхәммәд: «Ул тәхриреңне миңа бирче», – диде.* К.Насыйри

2) Язу рәвеше. *Шиһаб хәзрәтнең татарча тарзы тәхрире вә өслүб ифадәсе бу көндә һичкем тарафыннан ияреләчәк бернәрсә түгелдер.* Җ.Вәлиди

**ТӘХРИРЧЕ** *и.* 1) *иск.* Язучы, публицист. *Ул кавемнән булмыйдыр тәхрирчедән һичкем тыныч. Берсе бар, дустым минем, һәрбер сүзе үткен кылыч.* Г.Тукай

2) Террористик дип танылган «Хизб эт-тәхрир әл-Ислами» халыкара сәяси партия тарафдары. *Ниндн генә фиркалар, агымнар юк бит хәзер: сәләфиләр, тәхрирчеләр, ихваннар, тәкфирчеләр.* Туган як. *Тәхрирчеләрнең күбесенең, чынлап та, үзләре дә аңлап бетермичә, планлы рәвештә һәм тырышып, алар алдына максат итеп куелган – исламга булган ышанычны киметү мәсьәләсен хәл итү белән шөгыльләнүләре миңа аңлашыла башлый.* Дин вә мәгыйшәт

**ТӘХСИЛ** *и. гар. иск.* 1) Белем, гыйлем. *Каргалы мәдрәсәләрендә гыйльми тәхсил алу белән мәшгуль иде.* Т.Гыйззәт

2) Гыйлем алу, уку, белем алу шөгыле. *Анларның һәрбер шартларына разый булып, мәдрәсәгә керүче һәм гали тәхсилгә кызыгучы шәкертләр күп табылыр.* Г.Камал. *Ул уналты яшькәчә авыл мәктәбендә укыды да, атасы үлү сәбәпле, тәхсилен туктатырга мәҗбүр булды.* Г.Ибраһимов

**ТӘХСИ́Л ИТҮ** *ф.* Уку, белем алу, өйрәнү. *Сез могтәбәрдә гыйльме тәхсил итәргә килдек.* Т.Гыйззәт. *Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең, Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.* Г.Тукай

**ТӘХСИ́Л КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәхсил итү**. *Гомәр: «Безнең мөселманнар да мәгърифәт тәхсил кылырга тырышырга кирәк иде», – дип белдерә һәм уку-белемнең файдасын мисаллар белән раслый.* Г.Камал. *Мелла хаҗи Габидулла Бохараи шәрифтә тәхсил кылып кайткач, Казан өязе Сәрдә карьясендә имам булып, аннан күчеп, Сөрде карьясендә имам булган.* Р.Корбан

**ТӘХСИН** *и. гар. иск.* 1) Хуплау, нәрсәне дә булса яхшы күрү; берәр кешенең фикерен, эшен яхшы дип табу. *[Хәзрәт], рәсемдәге татарга тәхсин күзе белән карап: «Шулай, шулай, яр кабыргасын шайтан камчысының!» – дип кычкырды.* Ф.Әмирхан. *Бу фикерләр гакыл әһелләре тарафыннан тәхсин берлә каршы алынды, вафат тарихы артта кала барган саен, шөһрәте вә хөрмәте арта вә халыкларга якынлаша барадыр.* Безнең мирас

2) Мактау, соклану сүзләре. --- *һәммәсе Җәләлгә тәхсин әйттеләр, аның мондый зур һимматенә, ата-баба кыйла алмаган бер эш күрсәтүенә хәйрәтләрен бәян кыйлдылар.* Г.Ибраһимов. *Падишаһ бу сүзләрне вәзирдән ишеткәч, бәрәкаллаһ дип, мең төрле тәхсин укыды.* М.Гайнетдин

3) Иске мәктәп-мәдрәсәдә югары билге; яхшы, дүртле билгесе. *Миңа 9 яки 10 билгеләре алырга да насыйп булгалады, кайвакыт афәрин, тәхсин, имтиязлардан да өлеш чыга торган иде.* Р.Әмирхан. *Бу кәгазьгә караганда,*

*әүвәлге елларда иң итагатьле, «афәрин», «тәхсин»гә генә укып килгән Галимҗан мәхдүм, соңгы бер-ике ел эчендә бик бозылып, монафикъланып киткән икән.* Г.Мөхәммәдова

**ТӘХСИ́Н ИТҮ** *ф. иск.* Мактау белдерү, хуплау, яхшы күрү; соклану. *Бик бай булмаган бер гаиләнең болай матур тора белүенә гаять тәхсин иттем.* С.Максуди. *Моның өчен үземә-үзем дә тәхсин иттем.* Ш.Камал

**ТӘХСИ́Н КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәхсин итү**. *Хәзрәт тә байның «зирәклеге»не тәхсин кыйлып, ике мең сум илә төрекләрне ризалатырга карар бирделәр.* Г.Камал. *Остазы һәм тәхсин кылды Әмин байның оста булуына, ләкин, нә чара, бу бичарага зыян уларак, ел тулып, беркөнне Әмин байны конторадан дәшеп әйттеләр: – И Әмин бай! Ел тулды. Нә диячәксең? – диделәр.* Безнең мирас

**ТӘХТЕ́ ГӨЛЕ** *и. бот.* Бегониячәләр семьялыгыннан буынтыклы кызыл сабаклы, кызыллы-яшелле зур яфраклы, төбеннән үсентеләр җибәреп үрчи торган, төрле төсләрдә чәчәк ата торган төрләре булган күпьеллык гөл; бака гөле; **бегония**. *Тәрәзә төбендә ал чәчәкле тәхте гөле*

**ТӘҺАРӘТ** *и. гар.* Мөселманнарның, кайбер гыйбадәтләрне кыла алу өчен, билгеле тәртиптә аерым әгъзаларын юып, аерым әгъзаларына мәсех кылу юлы белән пакьләнүләре. *Тәһарәтең бардыр бит, Гарифулла?* А.Хәлим. *Күрәсең, госел, тәһарәт, намаз кебек ислам йолалары ярдәмендә җан вә тән сәламәтлеген саклау аша физик форманы һәм баш эшләвен камилләштерүгә ирешелә.* Р.Сафин

◊ **Тәһарәт алу** Мөселманнар кайбер гыйбадәтләрне кыла алу өчен билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп юыну. *Таибә абыстайның да мондый көнне әрәм итәсе килмәде: иртәнге чәйдән соң тәһарәт алып, озак кына җыенып, ниһаять, Хөршидне ияртеп, зиратка китеп барды.* Ә.Еники. *Иртән, кешеләр йокыдан уянганчы тәһарәт алып намаз укыйм дисәм, ванна бүлмәләренең ишеген таба алмыйм гына бит.* Ф.Ярулин. **Тәһарәт бозу** Табигый хаҗәтләрне үтәү, косу һ.б.ш. сәбәпле тәһарәтле хәлдән чыгу. *Юк, алар телевизордан авыз суларын агызып, тәһарәт бозып, бетмәс-төкәнмәс сериаллар карыйлар.* Р.Зәйдулла. **Тәһарәт бозылу** Яңадан тәһарәт алу ихтыяҗы барлыкка килү, тәһарәтсез хәлгә керү. *Әгәр кеше кече яки олы табигый хәҗәтләрен үтәсә, арттан һава чыкса, тәннән кан, эрен, сары су акса, авыз тутырып косса, йоклап алса һәм башка шундый очракларда тәһарәт бозыла.* Туган як. *Намаз укыган кешеләрне шушы авыру борчыса, аларга дәвалану тиз арада кирәк, чөнки һаман тәһарәт бозылуы, кием нәҗесләнүе, җәмәгатьчелек урыннарында, мәчеттә үзеңне уңайсыз хис итүе һ.б. көн дәвамында мәшәкатьләр тудырачак.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. **Тәһарәт сындыру** *к.* **тәһарәт бозу**. *Казакъ бае, рус кыяфәтле Галимҗанга артык өнәмичә карап торды да: «Мин тәһарәт сындырып чыгаем», – дип, ачык капкадан ишегалдына кереп китте.* А.Расих. **Тәһарәт сыну** *к.* **тәһарәт бозылу**. *Безнең тәһарәтебез сынды бугай. Тәһарәт яңартасы иде.* К.Тинчурин. **Тәһарәт төзү** *к.* **тәһарәт яңарту**. *Ул, кайтып керүенә тәһарәт төзеп, намаз киемнәрен киеп, икендегә китте.* Гали Рәхим. *Пакь бәндәләр үтеп китәрләр, кемнәрдә тәһарәт төзү булмаган, егылып төшәрләр.* Ф.Яхин. **Тәһарәт яңарту** Яңадан тәһарәт алу. *Мин тәһарәт яңартып керим әле.* Т.Гыйззәт. *Өйлә намазына дип тәһарәт яңарткан хәзрәт үзенең фамилиясен шул секундта «Йолдыз» битендә итеп күз алдына китерде.* М.Мәһдиев

**ТӘҺАРӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кемгә дә булса тәһарәт алдыру. *Күрше хатыннары берлән абыстай, Гөлйөзем әбине тәһарәтләндереп, аны да эчерде.* Г.Исхакый. *Мөхәммәд галәйһиссәлам, кемнең күзе тисә, шул кешене тәһарәтләндереп, суын җыярга һәм шуның белән Сәлманны госел коендырырга кушты.* Ф.Яхин

**Тәһарәтләндереп алу** Тиз генә тәһарәтләндерү. *Әтине тәһарәтләндереп алырга кирәк*

**Тәһарәтләндереп бетерү** Тәһарәтләндерүне төгәлләү, тәһарәтләнгән хәлгә китерү. *Тәһарәтләндереп бетергәч чакырырмын.* Р.Вәлиев

**ТӘҺАРӘТЛӘНҮ** *ф. к.* **тәһарәт алу**. *Алар, намазга кичегүдән куркып, тәһарәтләнергә дә онытканнар иде.* М.Галәү. *Тәһарәтләнгәндә, пәйгамбәр үзенең данлыклы йөзеген бармагыннан салып, Әминәгә биреп саклата иде.* Ф.Яхин

**Тәһарәтләнеп алу** Тиз генә тәһарәтләнү. *Яңадан урамга чыгып, чишмә суында тәһарәтләнеп алдылар, кыйбланы эзләп табып, кичке намазларын укыдылар.* Ф.Бәйрәмова

**Тәһарәтләнеп тору** Даими тәһарәтләнү, гел тәһарәтле булу. *Минем дусларым, ураза тотмыйммы дип, су эчертеп, намаз укымыйммы дип, аякларын карап йөргән (намаз укучыныкы чебиләми, гел юып, тәһарәтләнеп торгач) укытучыларны елап искә алалар.* Безнең гәҗит

**ТӘҺАРӘТЛЕ** *с.* Тәһарәт алган, тәһарәте булган. *Әмма мин, бу юлы тәһарәтле булсам да, мәчеткә керергә атлыкмадым.* Т.Әйди. *Мунчага кереп, бер кат чайканып чыксаң да ярар, мәет янында тәһарәтле булырсың.* Ф.Бәйрәмова

**ТӘҺАРӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Тәһарәте булмаган, тәһарәт алмаган, тәһарәте бозылган. *Бу кадәресен инде Мохтар абзый күтәрә алмады: «Тәһарәтсез, имансыз авызың белән кагыласы булма изге китапка!» – дип, туганнан туганына җикеренеп куйды.* М.Хәсәнов. *Гөлмия – үтә явыз кемсә: урамда очраса, син – тәһарәтсез, намазсыз, догасыз марҗа, дип бәйләнеп үтерә.* Н.Гыйматдинова

2) Тәһарәт алмыйча кылынган (гыйбадәт, намаз тур.). *Тәһарәтсез намаз уку белән бердер ул, димен.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Юынмаган, тәһарәт алмаган килеш. *Тәһарәтем бар, шөкер, тәһарәтсез йөрмим.* М.Хуҗин. *Төшләрне тәһарәтсез килеш юрарга ярамый, ди торгание минем каенанам, урыны җәннәттә булсын!* Г.Галиева

**ТӘҺАРӘТХАНӘ** *и. гар.-фар.* 1) Тәһарәт алу өчен махсус бүлмә яки бина. *Һәм күп өйләрдә тәһарәтханә хатыннар өчен башкача була.* К.Насыйри. *Беренче катта тәһарәтханә һәм ифтар*

*мәҗлесләрен оештыру өчен кечкенә аш бүлмәсе урнашкан.* Безнең гәҗит

2) Бәдрәф, хаҗәтханә. *Мин тышка чыккан җирдән, таһарәтханә ярыгыннан, күрше кызы Галимәне карап тордым.* Г.Исхакый. *Хуҗага болар гына аз тоелды: ул тирә-якта булмаганча иттереп таһарәтханә ясады, аның бер ягын ирләргә, икенчесен хатын-кызга тәгаенләп, ике бүлемле итте, электр үткәрде, өй күтәрмәсеннән ак плиталардан юл-сукмак сузды – патшалар да җәяү йөри торган җиргә ялан тәпи барырлык булды.* Д.Булатова

**ТӘҺӘҖҖУД** *и. гар.* Төнлә йокыдан торып укыла торган намаз. *Тәһәҗҗуд намазыннан соң исә дә, ул көн күп ашта булганлыгыңыз сәбәпле, ашыңыз сеңеп бетмәгән, күңелләрегез дә сафланып җитмәгән булырга кирәк!* З.Һади

**ТӘҺЛИЛ** *и. гар. дини* 1) «Лә илаһә иллә Аллаһ» («Аллаһтан башка илаһ юк») җөмләсен әйтү. *Сабый Аллаһы Тәгаләне искә төшерде, ишетәсеңме, Гыйммаделислам, «Лә илаһә илаллаһ!» диде – тәһлил әйтте, гомере озын булыр, Аллаһы боерса, сабыең Хак Тәгаләне мактап аваз салды.* Д.Каюмова

2) Җеназа мәрасименең бер өлеше: мәетне өйдән чыгарыр алдыннан, берничә кешенең тәсбих тартып, билгеле тапкыр «лә илаһә иллә Аллаһ» сүзләрен әйтеп Коръән укып багышлавы. *Бөтен авылның картлары тәһлилгә җыелды.* Г.Исхакый. *Картлар, кесәләреннән дисбеләрен алып, мәеткә багышлап тәһлил чыктылар.* Г.Галиев

**ТӘЧ** I *кис.* **1.** *диал. к.* **тач**. *Туп суның тәч уртасына барып төште*

**2.** *рәв. мәгъ.* Тулысынча, бөтенләе белән, бөтенләй. *Тәч яңа*

**ТӘЧ** II *иярт.* Нинди дә булса юеш өслеккә кинәт басканда, сукканда яки нәрсәгә дә булса төкергәндә чыккан тавышны белдерә. *Мирсәет уч төпләренә тәч итеп бер төкерде дә морза малаеның каршысына чыгып басты: – Җә, карап карыйк синең ак күмәчеңнең нәрсәгә яраганын.* Р.Мөхәммәдиев

**ТӘЧ-ТӘЧ** *ияр*т. **1.** *диал. к.* **тач** II. *Аның йөгереп киткәндәге аяк тавышлары монда кадәр ишетелеп калды: тәч-тәч.* Мәйдан

**2.** *ы. мәгъ.* Сарык чакырганда әйтелә; бәрәч-бәрәч, бәрә-бәрә. – *Тәч-тәчтәч! – дип, сарыгын чакырырга кереште.* Н.Әхмәдиев. *Сарыкларны «тәчтәч-тәч» дип чакырсак, алар безгә карап «бә-ә-ә-ә» дип бәэлдиләр.* Сабантуй

**ТӘШӘББЕС** *и. гар. иск.* Инициатива; бер эшкә керешү, тотыну, бер эшне башлап җибәрү. *Финляндиянең Тампере шәһәрендә «Тампере төркләре берлеге»нең тәшәббесе (инициативасы) берлә хөрмәтле Гаяз әфәнденең шәрәфенә бер милли кичә тәртип ителде.* Г.Исхакый. *Хуҗа Габделбәдигъның халык әдәбиятын тергезү юлындагы тәшәббесе шулардан бередер.* Ф.Сәйфи

**ТӘШӘББЕ́С ИТҮ** *ф. иск.* Керешү, башлап җибәрү, башлангыч бирү, инициатива белән чыгу. *Аңлы вә фикерле мөселманнардан бәгъзы кешеләрнең эшкә хәзердән үк тәшәббес итә башлаганлыклары күренәдер.* Г.Камал. *Гаспринский нинди нәрсәгә эш башласа, нинди нәрсәгә тәшәббес итсә, шул эштә вә шул тәшәббестә без бер бәрәкәт вә бер ныклык күрәмез.* Безнең мирас

**ТӘШӘББЕ́С КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәшәббес итү**. *Тимер, безнең орлыкны Тәшәббес кыл җыярга.* Ш.Бабич. *Төрек илчеханәсендә бу хосуска иганә җыюга тәшәббес кылынган икән.* Гасырлар авазы

**ТӘШӘББЕСЧЕ** *и. иск. кит.* Берәр эшне башлап җибәрүче кеше; инициатор. *Безнең төркемнең тәшәббесчесе ул*

**ТӘШӘККЕР** *и. гар. иск.* Рәхмәт; шөкер. *Вәлид торып утырып, тәшәккер тулган караш белән күзләремә карап, сүзсез генә минем кулымны кысты.* Гали Рәхим. – *Тәшәккер, бәй әфәндем! – дип мыгырдандым да сукраныбрак икенче ягыма әйләнеп яттым.* Т.Әйди

◊ **Тәшәккердән гаҗиз** 1) Бик нык шатлану, куанычтан нишләргә дә белмәү. *Пәйгамбәр тәшәккердән гаҗиз...* Г.Гобәй. *Мин, әлбәттә, борынгыча әйтсәк, тәшәккердән гаҗизмен!* Ә.Еники; 2) Күп рәхмәт әйтү. – *Тәшәккердән гаҗизмен, хөрмәтле шеф, – дип җавап бирде Муса.* Ш.Маннур

**ТӘШӘККЕ́Р ИТҮ** *ф.* Рәхмәт әйтү, рәхмәт белдерү. --- *кичәгә акча җыю һәм кичәнең тәртибенә карау эшендә күп тырышлык һәм мәхәббәт күрсәтүләре өчен тәшәккер итәргә үзебезне бурычлы саныйбыз.* Г.Исхакый. --- *Бохара кызлары арасында фикри инкыйлаб ясауга сәбәп булулары вә яшьләрнең сәхнәдәге кимчелекләре тутырылуы өчен күпме тәшәккер ителсә дә ярыйдыр.* Һ.Такташ

**ТӘШӘККЕ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тәшәккер итү**. *Вәгаләйкемәссәлам! Рәхмәт, тәшәккер кыламын.* Т.Әйди

**ТӘШВИШ** *и. гар.* 1) Шик-шөбһә, күңел тынычсызлыгы; тирән борчылу, дулкынлану хәле. *Эчең тулы борчу, җан кайгысы, тәшвиш булганда, тирә-юнь, табигать күзгә күренми икән.* Х.Камалов. *Шулай да мин, аның йөзендә ниндидер тәшвиш күләгәсен абайлап: – Иминлекме, Зөлфия? Сине нидер борчый төсле? – дип сорадым.* А.Тимергалин

2) Курку, шикләнү, шом. *Тау астында чуалыш, үлем, җан ачысы белән кычкырган хушлашу авазлары, өннәре алынган ат кешнәве, тәшвиш, өметсезлек, гарасат һәм мәхшәр!..* В.Имамов. *Бар, дисә, хәвеф-хәтәрдән, кызның күңеленә тәшвиш кертүдән курка.* Г.Гыйльманов

◊ **Тәшвиш салу** Кемнең дә булса күңелендә шик-шөбһә, курку тудыру. *Бу акыллы башның күңеленә тәшвиш салмасын иде дә аңа тәвәккәллек бирсен иде!* Ә.Еники. *Тузанлы юлда үзләреннән-үзләре барлыкка килеп биешә, тузгый башлаган нәни җен өермәләре генә ничектер күңелгә тәшвиш сала.* А.Тимергалин. **Тәшвишкә салу** Коткы, фетнә тарату, котырту. *Фәлән төрле ысул белән уку шәригатькә каршы, дигән кебек юк сылтаулар белән укуга, укытучылар һәм мәктәп тәрбия кылучыларга каршы төшүчеләр, рисаләләр бастырып, халыкны тәшвишкә салучылар һәм укытучылар өстеннән шикаять итүчеләр.* Р.Фәхретдин. *И монафикъ, син халыкны тәшвишкә салдың, аларга ялган сөйләп, вәсвәсә кылдың.* Ф.Яхин. **Тәшвишкә төшү** Куркып калу, шөбһәләнү, шикләнү; аптырап калу. *Күңел чоңгылының төбендә бөтерелә башлаган дул-*

*кыннарның ерак тавышын ишетеп тәшвишкә төшкән кеше кайчак, үзен үзе шулай алдап, хәвефтән котылмакчы була бит.* Г.Әпсәләмов. *Рәфис тәшвишкә төште.* А.Вергазов. **Тәшвиш төшерү** Курку кертү, коткы тарату, шом салу. *Русия мөселманнарының күңеленә тәшвиш төшерәчәк түгелдер.* Г.Исхакый

**ТӘШВИШЛӘНҮ** *ф.* Шикләнеп, шомланып борчылу, курку; тынычсызлану, аптырау. *Хатны алу белән ул әлсерәү йөрәкнең шундук аһ-ваһ тәшвишләнүе, әллә ниләр уйлавы бар бит.* С.Сабиров. *Зурдан кубып бимазаланырга, борчылырга, тәшвишләнергә сәбәп тә юк кебек.* Т.Галиуллин

**Тәшвишләнә бару** Торган саен күбрәк тәшвишләнү. *Шау-шу арткан саен, ул тагын да тәшвишләнә барды, күзенә беркем күренмәс булды.* Р.Вәлиева

**Тәшвишләнә башлау** Тәшвишләнергә тотыну. *Хатыным да минем бу төшләремә тәшвишләнә башлады.* Ж.Дәрзаман. *Әллә быел җәй булмыймы икән, Ходаем, дип тәшвишләнә башлаган картларның борчуын басарга теләгәндәй, күктә яңа ай тугач, көннәр дә аязып-рәтләнеп китте.* Шәһри Казан

**Тәшвишләнә төшү** Тагын да күбрәк тәшвишләнү. *Кыз тәшвишләнә төште*

**Тәшвишләнеп бетү** Тәмам тәшвишләнү, бик нык тәшвишләнү. --- *син кайтканны көтә-көтә, әниең тәшвишләнеп беткән иде.* Ш.Маннур

**Тәшвишләнеп калу** Нindидер хәл, вакыйга сәбәпле кинәт тәшвишләнгән хәлгә килү. *Сәет уйланып, тәшвишләнеп калды: ханымны өенә чакыру уе юк иде, ташлап китеп тә булмый.* Т.Галиуллин

**Тәшвишләнеп куюю** Аз гына тәшвишләнү. *Ә җиңгәсе, хәйләкәр Гыйльмениса, болай үзе ишетмәгәнгә салышкандай торса да, эченнән кинәт тәшвишләнеп куйды: «Тишекле сөяк җирдә ятмый, диләр».* Ф.Хөсни

**Тәшвишләнеп тору** Сөйләү моментында тәшвишләнү; озак вакыт дәвамында тәшвишләнү, һаман тәшвишләнү. *– Тәшвишләнеп торырга вакыт юк, аны барыбер безгә эшләргә, киттек әйдәгез, – диде ул, безгә карап та тормыйча.* Р.Вәлиев

**ТӘШВИШЛЕ** *с.* 1) Шиккә, куркуга, шик-шөбһәгә төшерә торган; шомлы. *Тәрбиячеләрнең һәм форма кигән надзирательләрнең чыш-пыш килүе, тәшвишле ыгы-зыгысы безне, әлбәттә, шомрайтты.* А.Тимергалин. *Аны тәшвишле четерекле хәлдән телефон чылтыравы коткарды.* М.Әмирханов

2) Шикләнүчән, шөбһәчән, куркучан. *Юк, бөтенләй беткән баш түгел икәнмен әле, дип, тәшвишле җанына тамчы хәтле генә канәгатьлек килде.* Х.Камалов

3) Шикләнә, шөбһә белдерә торган. *Егет, кызның тавышында тәшвишле аһәң ишетеп, туктап калды.* А.Гыйләҗев

**ТӘШКИЛ** *и. гар.* 1) Формалаштыру эше, оештыру процессы

2) Состав, бербөтенне оештырган нәрсәләрнең, затларның бөтенесе. *Мәсәлән, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов һәм Җ.Вәлиди татарларны «татар милләте» дип санасалар, Й.Акчура исә Казан татарларын бөтен Русия «төрек милләте»нең тәшкилендә күргән, ә С.Максуди Казан татарларын «төрек-татар милләте»нең шактый зур бер өлеше итеп санаган.* Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман

**ТӘШКИЛӘТ** *и. гар. кит.* 1) Икътисади, сәяси һ.б.ш. оешма. *Яңа икътисади тәшкиләтләр мөстәкыйль эшләргә өйрәнергә тиеш булачаклар.* И.Әмирхан

2) Учреждение. *Анда гарәп хәрефләреннән баш тарту һәм латинчага күчү кирәклеге әйтелә, партиянең район оешмаларына, матбугат органнарына, мәгариф буенча халык комиссариаты тәшкиләтләренә, латинчага күчүне көнүзәк мәсьәлә дип карарга, дигән күрсәтмә бирелә.* Р.Вәлиев

3) Берләшмә; кешеләр төркеме. *Мәрхүмнең җан тәслименнән соң кайтып төшкән балаларыннан, оныкларыннан үзенә күрә бер тәшкиләт оешырып, әниләренең һәм картәниләренең ахирәте Ләйлебәдәр карчык тешсез авызларын ләштер-лөштер китереп сөйләнә иде: «Бигрәк кенәләр дә изге җанлы кеше иде Сәлахетдин мәрхүмкәем!»* А.Хәлим. *Миңа калса, талантлы язучыларны, рәссамнарны, музыкантларны, театр әһелләрен бергә туплаган куәтле бер тәшкиләт корырга кирәк, ул тәшкиләт Татар конгрессы белән дә, депутатлар корпусы белән дә, Президент белән дә турыдан-туры хезмәттәшлек итәрдәй булсын.* Р.Батулла

**ТӘШКИ́Л ИТҮ** *ф.* 1) Хасил итү, гыйбарәт булу, булып тору. *Далада, күпчелек халкы атлы гаскәр тәшкил иткән җәмгыятьтә, җиңелчә җинаятьне җәзалауда таяк түгел, камчы, чыбыркы хәлиткеч роль уйнарга тиеш иде кебек.* Н.Фәттах

2) Барлыкка китерү, формалаштыру, оештыру. *Бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз күчерү тәрҗемә чылбырында әһәмиятле буынны тәшкил итә.* Р.Юсупов

**ТӘШРИФ** *и. гар. кит.* 1) Хөрмәт күрсәтү, олылау, зурлау, шәрәфләндерү. *Бу тәшрифең сәүдәгәргә тәэсир иткән, Шуның өчен рәхмәт укыр чын күңелдән ---.* К.Тинчурин

2) Кая булса да бару, килү белән шул урынны зурлау, шәрәфләндерү. *Бер милләтнең сәясәттә тоткан юлын күрсәтә торган нәрсәләрдән иң ачыгы ул – милләт падишаһының зурлык сатып-сатмавы, сарайларының зур булып-булмаулары вә аны зиярәт белән тәшрифенең тантаналар эчендә күмелеп-күмелмәведер.* Г.Бубый. *Гаяз әфәнде Исхакыйның чит илгә тәшрифе вакытында төшкән фотосы булырга тиеш ул.* Мирас

**ТӘШРИ́Ф ИТҮ** *ф. иск.* Үзенең килүе белән кемне дә булса олылау, шәрәфләндерү, хөрмәтләү; хөрмәт күрсәтеп кемгә дә булса бару, килү. *Берәр атна, ун көн үткәч, Троицкидан һәм кыргыз кардәшләремездән берничә затлар тәшриф иттеләр.* Г.Исхакый. *Имтихан күрергә теләгән ханымнар 9–13 сәгатькә кадәр мулла Габдулла Әмирхани йортына тәшриф итсеннәр.* Р.Әмирхан

**ТӘШРИ́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **тәшриф итү**. *Вә баручы адәмнең мәнзиләтенә күрә, тәшриф кыйлды яки тәшриф барды, диерләр.* К.Насыйри

**ТӘШТИТ** *и. гар. лингв.* Гарәп язуында хәрефнең икеләтелеп укылырга тиешлеген күрсәтә торган билге, хәрәкә. *Кайбер хәрефләрнең өсләрендә яки асларында төрле рәвешле аерым тамгалар булган. Аларны гарәпләр «тәштит», «һәмзә», «мәд» кебек исемнәр белән атаганнар.* Җ.Фәйзи

◊ **Тәштитен чыгару** *к.* **тәштитләү**. *[Кызлар] «Вәләзза-а-аллинн...» дип сузып, тәштитләрен чыгарып Коръән укыйлар.* К.Нәҗми

**ТӘШТИТЛӘ́Ү** *ф.* Җентекләү, җиренә җиткерү. *Хәзрәт һәртөрле курkуны онытып, кинәт тәштитләп каргарга, тиргәргә тотына.* Ә.Еники

**Тәштитләп тору** Озын-озак итеп тәштитләү. *Син аны, кем, Габделхак абзыйдан дип әйтмә. Нигә кирәк ул хәтле тәштитләп торырга?* Ф.Хөсни

**ТӘШТИТЛЕ** *с. лингв.* Тәштит куелган, тәштит белән укыла торган. *Кыпчак телендәге интервокаль -қ//-к – гадәттә элекке икеләтелгән-тәштитле ққ//кк дән килеп чыга ---.* Р.Әхмәтьянов

**ТӘЭМИН** *и. гар.* Тормыш, көнкүреш кирәк-яракларын булдыру, җитештерү яисә нәрсәне дә булса тормышка ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру эше. *Һәрбер кавем үзенең тереклеген тәэмин өчен, үзен үзе бетүдән саклар өчен, кулыннан килгәнчә тырышырга, хезмәт итәргә тиеш.* Г.Тукай. *Һәр кеше истикъбален тәэмин өчен дәртенә чара тапсын.* М.Гафури

**ТӘЭМИНАТ** *и. гар.* Билгеле бер оешма, завод-фабрика, кешеләр коллективы һ.б.ш.ның эшчәнлеге, тормыш-көнкүреше өчен кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итү эше. *Ул сугышка кадәр дә тәэминат эшендә эшләгән һәм Хөсәен Мостафин белән электән таныш булган.* М.Шабаев. *Болай карап торырга шактый йомшак булып күренгән тәэминат буенча урынбасары бер атуда берничә куянга тидергән ләбаса!..* М.Хәсәнов

**ТӘЭМИНАТЧЫ** *и.* Тәэминат оешмасында эшләүче кеше. *Тәэминатчылар иртәрәк шау-шу күтәргәннәр икән.* А.Гыйләҗев. *Тәэминатчылар төрле җирләргә чабалар, тик түбә материалы яки газобетон табылмый.* С.Рафиков

**ТӘЭМИ́Н ИТҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне тормышка ашыру өчен кирәкле матди шартлар тудыру; булдыру, яхшырту, көйләү. *Мин бит синең өчен, Алла каршында коточкыч гөнаһлар эшләп, башка берәүләрнең күз яшьләре белән, киләчәк тормышыңны тәэмин итәргә тырышам.* Т.Гыйззәт. – *Бүген үк, хәзер үк бөтенесен саклауны тәэмин ит, кырга каравылчылар куясыз, бер генә винтигына да кагыласы түгел, каравыл башлыгы итеп лично үзең билгеләнәсең, иртәгә хөкүмәт комиссиясе киләчәк, – диде.* М.Мәһдиев

2) Ихтыяҗларны канәгатьләндерү; кирәк нәрсәне биреп тору яисә бирьюлы бирү, тапшыру, булдыру. *Сәнгатькә өйрәтү ягыннан Тәнзиләдә әллә ни сәләт юк иде, ә менә занятиене оештыру, анда һәркемнең катнашуын тәэмин итү эшләрен шәп булдырды ул.* Г.Рәхим. *Аннары инде без сезне, яшь белгеч буларак, квартира белән тәэмин итү чарасын күрербез.* М.Хәсәнов

3) Нәрсәне дә булса булдыруга, үстерүгә, саклауга йогынты ясау, өлеш кертү, роль уйнау. *Телебезне, милли рухыбызны саклауда, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүдә бу шагыйрьнең роле искиткеч зур.* Х.Миңнегулов. *Аның сүзләренчә, татар халкын саклап калу, аңа хас рухилыкны тәэмин итү өчен, балага кечкенә яшьтән үк ислам динен сеңдерергә кирәк.* Р.Шакир

**ТӘЭМИ́Н КЫЛУ** *ф. к.* **тәэмин итү**. *Ата-анасы никадәр генә теләсә дә, матди ягын тәэмин кылырга гаҗизләктән аптырый.* Т.Әйди

**ТӘЭСИР** *и. гар.* 1) Үзара нинди дә булса бәйләнышка кергән, бәйләнышта торган нәрсәләрнең шул бәйләныш нәтиҗәсендә үзгәрешкә дучар ителүе; берәр кеше яки нәрсә тарафыннан икенче һ.б. кеше яки нәрсәгә ясалган йогынты. *Мөселман хатын-кызларның тормышына Интернетның тәэсире тагын да зуррак.* Н.Акмал. *Таулы өлкәләрдә агулы үсемлекләрнең тигезлекләргә караганда күбрәк очравы биеклекнең үсемлек составына тәэсире белән аңлатыла.* Агулы үсемлекләр

2) Берәр кеше яки нәрсә белән танышудан, очрашудан, аралашудан соң шул кеше (яки нәрсә) турында туган фикер. *Юк, мин башта... дорфа кыландым... бигрәк ямьсез тәэсир калдырганмын инде, әллә нинди мин... мине күпләр аңламый.* Г.Әпсәләмов. *Ә быелтыр көз бер мөселман мәрхүмне искә алу кичәсендә Әдһәм хәзрәт авырып килмәгәнлектән, аның өчен Коръән аятьләрен Фәгыйлә укый һәм тыңлаучыларда әйбәт тәэсир калдыра, җылы хуплау таба.* С.Сабиров

3) Тышкы дөнья күренешләренең, предметларның яки сүзләрнең кеше аңында, рухи халәтендә калдырган эзе, чагылышы. *Моңа әтинең тырышлыгы һәм мине чорнаган мохитнең тәэсире чиксез булды.* А.Хәсәнов. *Ә менә андый сәяхәтнең бүгенге көнгә тәэсире булмыйча калмас...* А.Тимергалин

4) Хисләнү, тойгылану, әсәрләнү күренеше. *«Кораб» шигырен ул, бәлки, шул сәяхәт тәэсире астында язгандыр.* М.Мәһдиев. *Бу язмам ул исән чакта ук, аның белән очрашу тәэсирендә язылган иде.* С.Мөхәммәтҗанова

**ТӘЭСИ́Р ИТҮ** *ф.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса берәр төрле йогынты ясау. *Дөрес, абзыемның миннән алда укып баруы бер яктан миңа бик яхшы тәэсир итте.* А.Хәлим. *Әле генә башына килгән фикер аңа яшен суккандай тәэсир иткән иде.* А.Гыймадиев

**ТӘЭСИ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **тәэсир итү**. *Шул юк-бар сүзне бетерер өчен, мәхдүмгә дә, Хәдичәгә дә чынлап тәэсир кылу юлыны иркенәйтер өчен, Хәдичәне хәзрәтләргә төшерергә булдылар.* Г.Исхакый. *Әмма әллә хисләр кайнарлыгы зиһененә тәэсир кылып, гакылы тәмам сафланып, хәтер почмагындагы йокымсырый башлаган күзәнәкләре капылт кына уянып киттеләр!* З.Хөснияр

**ТӘЭСИРЛӘНДЕРҮ** *ф.* Әсәрләндерү, тойгыларын кузгату, хисләндерү, күңелен йомшарту. *Тик әлегә ышаныч хисенең һаман арта, үсә баруы аны күбрәк тәэсирләндерә, ул хиснең тәмам ныгып җиткәнен түземсезлек белән көтә.* З.Хөснияр. *Сезнең хатыгыз һәм теләктәшлек күрсәтүегез мине бик нык тәэсирләндерде.* С.Ибраһимова

**Тәэсирләндерә бару** Торган саен күбрәк тәэсирләндерү. *Ул безне чынлап*

*та тәэсирләндерә бара, уйландыра, дулкынландыра.* Шәһри Казан

**Тәэсирләндерә төшү** Элеккегә караганда күбрәк тәэсирләндерү. *Укыган саен ул китап мине тагын да тәэсирләндерә төште, йотылып укый башладым.* Р.Вәлиева

**Тәэсирләндереп җибәрү** Тәэсирләнергә этәргеч бирү, сәбәп булу; бераз тәэсирләндерү. *Үзләре белгән җырны радиодан ишетү аларны шулай тәэсирләндереп җибәргән.* Ф.Яруллин

**ТӘЭСИРЛӘНҮ** *ф.* Берәр сүз, күренеш һ.б.ш.дан күңелдә көчле кичерешләр уяну, тойгылар кузгалу, әсәрләнү; күңел йомшару, хискә бирелү. *Җанланып, тәэсирләнеп, «Бәрәкалла! Сөбханалла!» дип кат-кат әйтерлек шул.* А.Хәсәнов

**Тәэсирләнә бару** Торган саен күбрәк тәэсирләнү. *Бу урамнарны күреп йөргәндә, мин тагын да тәэсирләнә бардым, күңелем нечкәрде.* Ш.Маннур

**Тәэсирләнә төшү** Тагын да күбрәк тәэсирләнү; бераз тәэсирләнү. *– Мин синнән калмыйм, – диде ул тәэсирләнә төшеп һәм елый башлады.* Г.Галиев

**Тәэсирләнеп бетү** Тәмам тәэсирләнү, бик нык тәэсирләнү. *Йөри-йөри тәэсирләнеп беттек, ару турында уйламадык та без ---.* Р.Камал

**Тәэсирләнеп җитү** Тәмам тәэсирләнгән хәлгә килү. *Тәэсирләнеп җиткән күңеленә шул сүзләр генә кирәк булган икән, күз яшьләрен сөртә-сөртә, әнисенә таба йөгерде ул.* Мәдәни җомга

**Тәэсирләнеп китү** Кинәт тәэсирләнү. *Мин тәэсирләнеп киттем, Тукайның Казан турындагы шигырен күңелемнән укыйм: «Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап».* М.Хәбибуллин

**Тәэсирләнеп тору** Озак вакыт дәвамында тәэсирләнү; хәзер, сөйләү моментында тәэсирләнү. *Аларның нәфис бизәкләренә сокланып, читкәрәк китеп, озын-озак итеп карап, тәэсирләнеп тора.* Т.Галиуллин. *Кыз исә кайнар күз яшьләре булып аккан сагышын тиз генә басып куя алмады, шулай аптырап, тәэсирләнеп торган килеш, кулы белән ишарәләп, Мусаны үз янына менәргә чакырды.* Г.Гыйльманов

**ТӘЭСИРЛӘНҮЧӘН** *с.* Тиз тәэсирләнә торган. *Ул бала чагында ифрат дәрәҗәдә җанлы вә уйнак табигатьле булуы белән бергә, назлы, дикъкатьле, тәэсирләнүчән иде.* Ш.Камал. *Сабый күңеле үтә тәэсирләнүчән бит ул.* Ә.Рәшит

**ТӘЭСИРЛӘНҮЧӘНЛЕК** *и.* 1) *биол.* Тышкы тәэсиргә бирелү хасияте, ярсучанлык. *Организмның тәэсирләнүчәнлеге*

2) Тиз тәэсирләнү үзлеге; сизгерлек. *Үзенә генә хас тәэсирләнүчәнлек, зирәклек бар иде аңарда.* А.Гыйләҗев. *Әйләнә-тирә дөньяны һәм шәхси кичерешләрне кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта.* Мәдәни җомга

**ТӘЭСИРЛЕ** *с.* **1.** 1) Тирән тәэсир, тойгы, хис тудыра торган. *Күргәзмә искитәрлек тәэсирле иде, мин заллар буйлап йөргән чагында, С.Хәким утырып та торды.* Н.Нәҗми. *Бу җыр – Илһамның «Карурман»ыннан кала иң куәтле, иң тәэсирле җырыдыр, мөгаен.* Р.Батулла

2) Кешенең холык-фигыленә, эшенә, карашларына һ.б.ш. йогынты ясарлык, тәэсир итәрлек. *Йөгерешкә китәсе кешенеке сыман, аның йөрәге дөпдөп типте, һәм шуңа күрә баштарак аның сүзләре бик тәэсирле булып, чын күңелдән сөйләнгән шикелле булып яңгырады.* Н.Фәттах. *Бер үк заманда, бер мохиттә яшәгән, иҗат иткән «тере классиклар»ның йогынтысы аеруча җанлы, тәэсирле була.* Л.Шагыйрьҗан

3) Абруйлы, хөрмәтле; вазифасы, эшчәнлеге һ.б. белән хөрмәт казанган, үз фикере, карашы булган; йогынтылы, сүзе үтүчән. *Яхшы костюмлы, яхшы ботинкалы, дәрәҗәле, «тәэсирле» иптәшләр арасында мин бар.* М.Мәһдиев. *Камил әфәнде Сарытау өлкәсенең иң бай һәм иң тәэсирле кешеләреннән берсе санала.* А.Шәймәрдән

**2.** *рәв. мәгъ.* Тирән хис, тәэсир тудырырлык итеп. *Совет халкының Ватан сугышында биргән корбаннарын шундый тәэсирле итеп сөйләде!..* А.Гыйләҗев. *Ибраһимов шушы «Яз башы» хикәясендә хис-тойгыларны тәэсирле итеп сурәтләп килә-килә дә, иң югары ноктага китереп җиткергәндә, әсәренә хыялый, мифик-әкияти юха, аждаһа турындагы хәбәрләрне кертә.* Ф.Яхин

**ТӘЭСИРЛЕЛЕК** *и.* Тәэсирле булу сыйфаты, тәэсир итү дәрәҗәсе. *Шулай итеп, авыл реализмы агымы татар әдәбиятына төрле стильләр, юнәлешләргә хас алымнарны тәэсирлелек арттыру чарасы итеп кулланучы күп әсәрләр бирде.* Р.Батулла. *Язучы өчен фольклор сәнгать осталыгы, шигъри тәэсирлелек үрнәге генә түгел, халыкның тормышын, омтылышларын, психологиясен һәм әхлагын аңлату чыганагы да булып тора.* Мәдәни җомга

**ТӘЭССОРАТ** *и. гар. кит.* Кемнең дә булса аңында, рухи халәтендә тышкы дөнья күренешләре, кешеләр һ.б. калдырган, тудырган тойгылар, тәэсирләр, эзләр һәм аларга бәйле кичерешләр. *Габделнурны биләп алган тәэссорат Рәйсәнәгә дә ят түгел иде.* Р.Кәрами. *Иң үтемле дәва – яки җылы сүз, яки яхшы тәэссорат икән ләбаса!..* З.Хөснияр

**ТӘЭССОРАТЛЫ** *с.* 1) Төрле күренешләрдән, вакыйгалардан, сүзләрдән һ.б. күңеле тиз йомшара, нечкәрә торган, тиз әсәрләнүчән. *Соң дәрәҗәдә тәэссоратлы, соң дәрәҗәдә хыялый Мөхәммәт ялгызлыкка бирелә.* Г.Гобәй. *Ул ифрат дәрәҗәдә тойгылы, чиктән тыш тәэссоратлы, хисле бала булып үсте.* М.Әмирханов

2) Тәэсирләнгән. *Ни әйтсәң дә, күңелнең бик сизгер, бик нечкә, бик тәэссоратлы чагы.* М.Хәсәнов

3) Көчле тәэсир итә торган, тирән тойгы, хис тудыра торган; тәэсир итәрлек. *Моңа, күрәсең, вакыйгалар ишелеге, аларның артыграк та тәэссоратлы булуы комачаулагандыр – югарыда сөйләгәннәр шуңа дәлил.* М.Хуҗин. *Якты ай һәм аның йөз нуры икесе дә бердәй гүзәл, бердәй тәэссоратлы түгелләрмени?* Ф.Яхин

**ТӘЯММҮМ** *и. гар. дини* Су булмаган җирдә кулны ком, тузан һ.б.ш. туфрак затына тидереп тиешле әгъзаларны сыпырудан гыйбарәт таһарәтләнү. *Мохтарның бала вакытында мәктәптә таһарәт, тәяммүм мәсьәләләрен укыганлыгы исенә төште һәм хәзердә дә каберлек шикелле урыннарда муллалар, мөәззиннәр өчен ул кулланмаларның*

*кирәге бетмәгәнлек аңа кызык тоелды.* Ш.Камал. *Ул икенде намазыны тәяммүм берлән генә, хәзрәтнең рөхсәте вә фәтвасы берлән утырып кына укый алса да, ахшам намазыны бөтенләй кыла алмады.* Г.Исхакый

◊ **Тәяммүм алу** Ике кулны ком, балчык ише туфрак затына сугып, йөзне, беләккә кадәр кулларны сыпырып тәһарәтләнү. *Кичә ясту намазына хәле китте, тәяммүм алып кына укыйм мин, диде.* Туган як. **Тәяммүм сугу** *дини к.* **тәяммүм алу**. *Тәһарәт алырга оныткан булсалар, тәяммүм сугып укырга мөмкин ич.* Ш.Камал. **Тәяммүм ташы** 1) *дини* Тәяммүм кылу өчен һәрвакыт янда йөртелә торган таш; 2) Күп йөреп, күпне күреп шомарып, остарып беткән кеше

**ТӘ́ЯН** *рәв. гар. диал.* 1) Һаман, гел генә, бик еш. *Тәян ал да гөл булмый.* Мәкаль. *Гадәт-сыйфатларың безнеке, ләкин бисмилланы тәян онытасың, ашагач, бит сыйпамыйсың, намазтәһарәт турында әйтеп тә тормыйм. Син кем?* И.Хуҗин

2) Бөтенләй, нәкъ. *Кыз тәян анасына охшаган. Егет тәян авылча киенгән*

3) Гел, барысы да. *Биш бала үстерде, тәян егетләр генә, бер кызы да юк*

**ТВИСТ** *и. ингл.* 1) XX гасырның 60 нчы елларында популяр булган, уртача тизлектәге, күпчелек очракта импровизация рәвешендәге парлы ритмик бию. *Пароходта узган бал-маскарадта твист биеп, бүләк алдык.* Г.Бәширов. *Яшьләрнең күбесе булдыра алмаганны эшли ала: ул твист биергә оста.* М.Мәһдиев

2) Шундый биюнең музыкасы. *Тыңлаганнары – буги-вуги, твист, блюз, ритм-н-блюз ---.* Кәеф ничек?

**ТЕАТР** *и. гр.* 1) Чынбарлыкны тамашачылар алдында куелган сәхнә уены аркылы чагылдыра торган сәнгать төре. *Театр дөньясында зур абруйга ирешкән Наилә Гәрәева, Ирек Баһманов, Вадим Кешнер – аның партадашлары.* Л.Хәмидуллин. *Шәүкәт абый Биктимеров, ахырдан сүз алып, болай диде: «Татар ул – театр яратучы халык ---».* Э.Фатыйхова

2) Бер язучының яки драма мәктәбенең барлык драма әсәрләре

3) Тамашалар оештыру белән шөгыльләнә торган учреждение, оешма. *Түбән Камада өч театр эшли. Чаллы театры уңышларга ирешеп килә. Минзәлә театрын саклап калуга ирештек.* Ю.Сафиуллин // Шуның коллективы. *Бу әсәрне театр Ленинград шәһәренә гастрольгә дә алып бара, һәм анда да спектакль сәхнә сәнгате буларак бик югары бәяләнә.* Д.Гыймранова

4) Тамашалар оештырыла торган зал, бина һ.б.ш. урын. *Мәсәлән, Мохтар Мутин турында болай дип сөйлиләр: ул, театрга барып җитәргә бер квартал кала такси тотып, театр каршындагы тамашачылар янына таксидан гына килеп төшкән.* Р.Миңнуллин. *Хәзер, менә шушы минутларда, театр фойесында атаклы җырчы белән очрашу булачак!* М.Вәли-Барҗылы // Шул тамашаның үзе. *Утырышып беткәч, театр башланды дигәндә генә, бер-бер артлы телефон шалтырарга тотынды.* Э.Фатыйхова

5) *күч.* Берәр вакыйга бара торган урын, билгеле күренешнең җәелү киңлеге. *Сугыш хәрәкәтләре театры. Анатомик театр*

6) *күч.* Тамаша, кәмит. *Миңа күңелендәгесе теленә күчкән өлкәннәрне тыңлап яту кызык: бушлай театр, тормыш мәктәбе.* Т.Галиуллин. *Галимхан салган көнне кибет яны, капка төбе гөрләп тора: түләүсез театр.* Р.Батулла

**ТЕАТРАЛ** *и. рус* Театр сәнгатен яратучы, театр сөюче, театрга еш йөрүче кеше. *Ул атаклы театрал, премьераларны калдырмый.* А.Гыйләҗев. *Минем аркада минем кул астында эшләүчеләр дә театрал булдылар.* Т.Миңнуллин

**ТЕАТРАЛЬ** *с.* 1) Театр сәнгате белән бәйле, театрга караган. *Суфия тәтәм – татар хатын-кызларыннан беренче булып югары театраль белем алган кеше.* Р.Батулла

2) Эчтәлеге, асылы белән театрга караган; тамашачылар алдында башкарыла торган. *Алар Тукай әкиятләре, шигырьләре нигезендә театраль композицияләр, тамашалар күрсәтте.* М.Вафин. *Тамаша төрки халыклар театрларының бәйрәм парады һәм зур театраль концерт белән ачылачак.* Г.Шәйхетдин

3) *күч.* Ясалма; гади, табигый булмаган, күрсәтеп, махсус эшләнгән. *– Хәсбиева! – диде ул, театраль тавыш белән. – Мин сезне сөям.* М.Мәһдиев

**ТЕА́ТРЧЫ** *и.* 1) Театр әһеле, театрда эшләүче кеше. *Иҗат эшендәге яңалык, алга китеш һәм үсешләрне бары форма тармагындагы яңалыклар белән генә билгеләү, бары формаль җитешлекләр артыннан гына куу – байтак язучы, театрчы иптәшләребезгә хас нәрсә.* М.Җәлил. *Сәхнәдә уйнамаучы театрчы да була икән, әй!..* Г.Гомәр

2) Театр сәнгатен тикшерүче галим; театр тәнкыйтьчесе. *Ләкин татарның борынгыдан театрлы, тамашалы халык булганы галимнәрнең, театрчыларның башына да килми.* Р.Батулла

3) Театр һәвәскәре, театр карау яки кую, театр оештыру белән мавыгучы. *[Хөсәен:] Бөтен мөселманнарның театрчыларга укыган ләгънәтләре синең башыңа да төшәчәктер.* Ф.Әмирхан

**ТЕА́ТРЧЫЛЫК** *и.* Театр сәнгате һәм шуның белән бәйле эшчәнлек өлкәсе

**ТЕВТОН** *и. лат.* 1) Эльба елгасының түбән агымында б. э. I гасырына кадәр яшәгән борынгы герман кабиләләреннән берсе һәм шул кабиләнең бер вәкиле

2) Немец рыцарьларының XII гасырда нигезләгән Герман (Тевтон яки Немец) ордены әгъзасы. *Ә без рыцарьлар турында ниләр беләбез? Мәгълүм булуынча, урыс кенәзе Александр Невский Чуд күлендә Тевтон ордены рыцарьларын тар-мар итә.* Кызыл таң

3) *күч.* Герман милитаризмы, немецларның хәрби көч куллану традицияләре

**ТЕГӘЛӘ́Ү** *ф.* Дикъкать белән караш юнәлтү. *Разия миңа карамаскарак тырышты, аның янындагы кызларның һәр икесе бик тегәләп карап уздылар.* Ф.Әмирхан. *Актырнак икенче янга борылып, күзен янә чебешләргә тегәли.* Ак юл

**ТЕГӘРҖЕП** *и.* Тупас тукыма, киез, күн һ.б.ш. калын материалларны тегү өчен хезмәт иткән нык, башкалардан күпкә юанрак җеп. *Бер кисәк сабынның яртысын тегәрҗеп белән кисеп алдым да перчаткаларны күтәреп чыгып бара идем, каршыма әнкәй килеп чыкты.*

М.Маликова. *Бүрәнәгә кагылган кадакларда төрледән-төрле бордау, пычкы, калын тегәрҗеп, линейкалар эленгән.* Р.Низами

**ТЕГӘРҖЕПЧЕ** *и. иск.* Тегәрҗеп эрләү белән шөгыльләнүче һөнәрче; тегәрҗеп белән сату итүче вак сәүдәгәр. *Безнең Гафур абзый тегәрҗепче түгел. Аның җеп белән эше юк.* К.Нәҗми

**ТЕГӘ́Ү** *ф. к.* **текәү**. *Күзгедән сылу гәүдәле, озынчарак йөзле, түгәрәк якты маңгаен бизәүче кара миңле, дулкын-дулкын карасу чәчле Саура кара күзләрен тегәп карый иде.* М.Хуҗин

**ТЕГЕ** *а.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса сөйләүчедән читтәрәк торганы; аргы, ераграктагы; *киресе*: **бу**. *--- колхоз зур каз-үрдәк фермасы ачып җибәргән, хатын-кызларның күбесе шунда чуала, ир-ат теге ярдагы районе белән бу як арасында Агыйдел аркылы паром йөртә ---.* Ф.Хөсни

2) Монысы түгел, башкасы, икенче бер. *Таксидан шактый гына әйберләр: төеннәр, кәрзиннәр, ящиклар төште, ләкин теге вакыттагы кебек нәфис чемоданнар төшмәде, музыка кораллары салынган футлярлар да күренмәде.* Ф.Хөсни. *Теге килгәндәге кебек йөрәгең тотса.* З.Зәйнуллин

3) Әйтеп үтелгән, алда телгә алынган, баягы. *Ялт итеп кенә чыгып, теге абый турында сорашып керсә? Әнисе сизми дә кала ич!* А.Гыйләҗев. *Мин ул, минем якка карамаска тырышып, җәһәт кенә теге зәңгәр туфлиләрне киде дә йөгерә-атлый урамга чыгып китте.* Г.Якупова

4) Инде билгеле булган, мәгълүм

5) Шул ук җөмләдә күрсәтелгән берәр билгесе, үзенчәлеге буенча мәгълүм. *Теге чакта, университетка керә алмыйча кире кайткач, ронодан мине Баллыболын мәктәбенә пионервожатый итеп җибәрделәр.* М.Маликова. *Теге бездән ике курс түбән укыган, беркайчан да тормышка ашмаячак әллә ниткән проектлар сызучы Имаметдиновмы?* Г.Рәхим

6) *күч.* Сөйләшүчеләргә генә билгеле булган, үзара гына аңлашыла торган урын, вакыт яки зат. *Мин болай дип яздым: «Теге мәсьәлә тикшерелде, рәис урыныннан алынды, хәзер колхозның эше көйләнеп килә».* А.Расих. *– Әйдә, Хәкимулла абый, борчылма, тегенең эзенә төштем мин,– диде. – Ташлытауга апаларына барып кергән.* М.Мәһдиев

7) Ни сәбәпледер атап әйтәсе килмәгән зат яки әйбер. *Шуннан теге, табып бирегез кызыгызны, дип, башта әнине дә, әтине дә кыйнаган, аннары аларның күз алдында безнең өйне яндырган.* В.Нуруллин

8) Сөйләшүнең объекты хакында сүз барган зат яки әйбер. *Комендант аның җилкәсенә бармак очы белән кагылуга, теге борылды, кыз кеше икән, юаш кына чырайлы иде.* Х.Камалов. *Теге, хуш исле печән чабып, арбага түшәде дә кинәт миңа карап туктап калды.* Г.Рәхим

**2.** *кис. мәгъ.* Инде, тагы, бит, ла, лабаса. *Син теге пуртәфиль тоттым дигәч тә...* М.Мәһдиев. *Үз иремнең тавышын Шәрәфинең булыр-булмас тавышы белән бутарга мине сез әллә теге юләр дип белдегезме?* Р.Батулла

◊ **Теге дөнья** *эвф.* Ахирәт. *Кешеләр теге дөньядагы җәзадан куркып кына ышаналармы, әллә тагы биредә берәр тылсым бармы?* Х.Камалов. **Теге дөньяга җибәрү** Үтерү. *Башта Батталны теге дөньяга җибәрергә иде.* Т.Гыйззәт. *Кешене вакытсыз теге дөньяга җибәрүче – Малышев дигән җинаятьче.* Ә.Баян. **Теге дөньяга китү** Үлү. *Дәү әтисенең вафатыннан соң кечерәеп, ятимләнеп калган карчык әйтерсең карты артыннан теге дөньяга китәргә әзерләнеп йөри иде.* И.Хуҗин. *Иман бит ул сәламәтлек беткәч, картлык үкчәгә баскач, Газраил якадан алгач, теге дөньяга китәр вакыт җиткәч кенә кирәк.* Д.Салихов. **Теге дөньяга күчү** *к.* **теге дөньяга китү**. *Теге дөньяга күчә башлаган кешенең аягы-кулы, бөтен тәне салкын булырга тиеш иде кебек.* Н.Фәттах. *--- бу мәсьәләне күбрәк авыру кешеләр кузгата, суд юлларында еллар буе йөри торгач, алар тын гына теге дөньяга күчәләр.* Ф.Бәйрәмова. **Теге дөньяга озату** *к.* **теге дөньяга җибәрү**. *Бу этне теге дөньяга озаткан кешегә орден бирергә кирәк, диде Кәлимуллин, юри милиционерларның ачуын китерү өчен, һәм кул селтәп китеп барды.* Х.Камалов. *Дүрт җиргә куелган күзәтчеләрне шома гына теге дөньяга озаттык.* Р.Сәгъди. **Теге дөньяга олагу** *туп. к.* **теге дөньяга китү**. *Нигә ул, ир уртасы, гакылы тупсага утырырга тиешле кеше, әбер-чебер, малайшалай уеннарына катнашып, юлларда атышып йөри? Чут-чут теге дөньяга олакмады.* Т.Галиуллин. *Фәрманыгыз үтәлде, бөек ханым. Акылгали, агулы чишмә суы эчеп, теге дөньяга олагачак.* Г.Сабитов. **Теге дөньяга олактыру** *туп. к.* **теге дөньяга җибәрү**. *Азат Айсылу аркасында кулга алына язуын башына да китерә алмады. Чөнки бар булган шаһитларны теге дөньяга олактырды.* Р.Сәгъди. *Бүген ул Азатны теге дөньяга олактырачак.* З.Мәхмүди. **Теге яки бу** Кайсыдыр, берәр, нинди дә булса. *Югарыдагылар халык сүзенә колак салмыйлар, дисәк тә, җәмәгатьчелектә теге яки бу фикер өлгерми торып, власть башындагылар бик селкенми.* Ф.Яруллин

**ТЕГЕ-БУ** *а.* (тегенең-моның, тегеңәмоңа, тегене-моны, тегеннән-моннан, тегендә-монда) 1) Һәртөрле нәрсә, теләсә нәрсә. *Бушаган стаканга ул яртыга якын итеп аракы салды һәм, тегебу турында сөйләнгәләп, һаман үзләре янында басып торган Исламга сузды.* Н.Фәттах

2) Берәр нәрсә, нәрсә дә булса, нидер. *Лена да алар янынннан узып-узып киткәли. Алар белән юк-бар сүз алышкан булып, кырыйларында туктала. Тегебу кирәкмиме, дип сораша.* М.Вәлиев

3) Берәр төрле; теләсә нинди. *Кичкә хәтле бабагыз чишмә һәм елга тирәсендә әйләнер, аннары абзар-курада теге-бу эш табып вакыт уздырыр, эңгер төшкәч кенә, анда да түр якка узмыйча, алгы бүлмәдәге диванга утырып ял итәр.* Ә.Баян. *Һәр Ходай бирмеш көнне Тавис иртүк атын җигә дә фермага китә. Эшкә карусыз, бригадир аның теге-бу эшне өзгәнен, каршы килгәнен белми.* М.Мәһдиев

4) Юк-бар, вак-төяк нәрсәләр яки әһәмиятсез кешеләр. *Мин бит сезгә теге-бу түгел!* Р.Батулла. *Теге-бу түгел, Халисә җиңгинең олы малае тагын да калынаеп, типсә тимер өзеп,*

*авызына сигарет капкан кыяфәттә кайтып төште.* Ф.Яхин

◊ **Теге-бу булу** Берәр көтелмәгән хәл, күңелсезлек килеп чыгу, хәл начар якка үзгәрү. *Мәскәүгә китеп эшли башлагач, туган ягымны сагынудан теге-бу була калса дип, алдан ук язып куйдым.* Г.Бәширов. *Менә ул кайдадыр йөри, ә син аның һәр адымын йөрәгең белән озата барасың, теге-бу булмагае дип куркып торасың.* Х.Камалов

**ТЕГЕЛӘЙ** *а.* **1.** 1) Теге якка, күрсәтелгән юнәлештә. *Син инде әнә тегеләйрәк, келәтләр алдынарак барып бас.* З.Зәйнуллин

2) Теге якта, тегендә. *Сәүдә залы тегеләйрәк урнашкан.* Ә.Дусайлы. *Мәһабәт баскычлы бина төзеләчәген белсә, моннан йөз еллар элек бу агачка җан өргән кеше аны тегеләйрәк утырткан булыр иде.* М.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Арырак, ераграк. *– Кайда? – Әнә тегендә, астарак, яшен суккан чыршыдан тегеләйрәк.* Н.Фәттах. *Урын бир кунакка. Тегеләйрәк бар!* Г.Сабитов. *Хәләф Борһанович, кинәт күңеле төшеп, ачуланып, хатынына терсәге белән төртте: – Кит тегеләйрәк!* Т.Гарипова

2) Башкача, үзгәчә, икенче төрле; башка рәвешле. *Сызымнарга, макетка кызыксынып карадылар, сораулар яудыра башладылар, тегесен болайрак, бусын тегеләйрәк итәргә кирәк иде дип, теләкләр әйттеләр.* М.Маликова

3) Нигездә, гомумән алганда; гадәттә. *Хәйбулла иптәшне тегеләй без акыллы кеше дип беләбез.* Ш.Камал. *– Ә тегеләй ничек? – Тегеләй өч ел бергә укыдык. Бер бүлмәдә яшәдек, ул укытучы булырга дип әзерләнгән иде.* М.Мәһдиев

4) Теләсә ничек; кирәкмәгән, килешмәгән рәвешле. *Тик менә килендәш кенә тегеләйрәк булып китте бит әле, кениш.* В.Нуруллин. *Имеш, ул тегеләй булган икән, егетләр белән шаярган икән, ниндидер хилафлыгы беленгәч, Варистан киткән, ди.* Х.Камалов

**3.** *кис. функ.* Әйтелгән фикерне көчәйтү өчен кулланыла. *Район прокуроры белән тикшерүчеләргә ришвәт бирде дип, бөтен дөнья сасыр, күзеңне дә ачырмаслар тегеләй!* М.Хәсәнов. *Безнең якта көр ат күрсәләр, сырт өстендә йомырка торырлык, дип әйтәләр иде. Моныкында өч йомырка тәгәрәтерлек тегеләй.* Г.Сабитов

◊ **Тегеләй генә** Болай гына, аерым максатсыз, җитди уй белән түгел. *[Бикә:] Сиңа нәрсәгә! Кызыктыңмыни? [Килен (кызарып):] Тегеләй генә сорыйм.* Г.Исхакый. **Тегеләй дә** Болай да, шул килеш тә, шуннан башка да. *Бу арада тегеләй дә бик гасабилана башладым бугай.* Г.Әпсәләмов. *Театрга тегеләй дә ошый иде, ә хәзер һәйбәтләнде төсле.* Н.Нәҗми. **Тегеләй дә болай** Гаеп итү, тәнкыйть сүзләре, гайбәт турында. *Соңыннан тегеләй дә болай, фәлән дә фәсмәтән дип йөрерлек булмасын!* В.Нуруллин. *Имеш, Византия архитектурасына охшатып заманча салганнар икән дә, тегеләй дә болай, алай да тегеләй.* Р.Сәгъди. **Тегеләй дә, болай да** Һәм шулай, һәм башкача; теләсә ничек, ничек тә. *Тегеләй дә итеп карыйм, болай да маташтырам, юк кына.* Г.Рәхим. *Тегеләй дә, болай да ятып карады ул, һаман урынның җаен тапмады.* М.Маликова

**ТЕГЕЛӘ́Й-БОЛАЙ** *рәв.* **1.** 1) Төрле юнәлештә, әле бер якка, әле икенче якка. *Әбекәе, --- табагач белән табаны тегеләй-болай боргалаганнан соң, берара җитез генә хәрәкәт белән көлчәне кабат теге кызыл шакмаклы ашъяулыкка төшерә дә өстен тастымал белән каплап куя.* А.Юнысова

2) Ике якка, бару һәм кайтуны исәпләп. *Ерак болынга да барып карады. Тегеләй-болай биш чакрым. Яңа басудан да эзләде. Тегеләй-болай алтыҗиде чакрым.* Р.Батулла

3) Теләсә ничек, теләсә нинди рәвештә, берәр ничек; теләсә кая; теләсә кайда. *Тик шуны истә тот, Биксылу: тегеләй-болай хәйләләмәскә!* Ф.Яруллин. *Нигезне ятим итәсе килмәсә, йөрмәсен тегеләй-болай тәгәрәп, даладагы дүңгәләк шикелле.* Г.Якупова

4) Саксыз, тәртипсез, тәрбиясез, законсыз һ.б.ш. рәвешле. *Тегеләй-болай кыланырга бит акча кирәк, ә аны каян аласың?* М.Мәһдиев. *Тегеләй-болай кактырып-суктырып сөйләшкән булалар. Сизәм, куркытырга исәпләре.* Т.Миңнуллин

5) Аннан-моннан, тиз-тиз генә, җиренә җиткермичә, җитди якын килмичә. *Димәк, бәйрәмне тегеләй-болай гына түгел, чын күңелдән итәләр.* Г.Бәширов. *Өйгә кайтып тегеләй-болай гына капкалап чыгып йөгерергә туры килде.* М.Мәһдиев

6) Җиңел генә, җайлы гына, артык тырышмыйча. *Тегеләй-болай гына кулга төшерерлек түгел дә түгел инде [кызны].* К.Миңлебаев

7) Очраклы рәвештә, махсус түгел, ялгыш кына; аерым максатсыз. *Хәзер инде ул машина белән үз йортына бик сирәк кайтты, тегеләй-болай кулга кергән нәрсәләрен Даниягә түгел, бәлки бүтәннәргә ташыды.* Н.Фәттах. *Энем, шаярма. Хаҗимулла абзаң җитди кеше, тегеләй-болай гына йөрмидер.* Г.Каюмов

8) Уйламыйча, юри генә, җитди рәвештә түгел. *[Рәхим:] Самомдили яздыңмы? Әллә тегеләй-болай сызгаладыңмы? [Гыйззәт:] Ни дигән сүз инде ул? Билгеле, яздым.* Һ.Такташ. *Ә син, егетем, чынлап өйрәнергә телисеңме? Әллә тегеләй-болай гынамы?* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төрле, теләсә нинди. *--- синең тегеләй-болай уйлануларың, шикләнүләрең аларны кызыксындырмый, алар үзләре уйлый белә.* Г.Әпсәләмов

2) Бик үк әйбәт булмаган, уртача сыйфаттагы, ни җитте шундый

**3.** *хәб. мәгъ.* Әлләни әйбәт түгел, уртача. *Узгегез беләсез, безнең эшләр ул чагында тегеләй-болайрак кына иде.* С.Сабиров

**4.** *и. мәгъ.* 1) Нәрсә дә булса, берәр нәрсә, ниндидер хәл. *Мин бит тамгалы карга, тегеләй-болай була калса, ансат кына миңа ягачакларын беләм.* Н.Әхмәдиев. *Тегеләй-болай диярлек дәлилләрем дә, вакланып йөрергә вакытым да юк.* М.Хәсәнов

2) Берәр көтелмәгән, гадәттә күңелсез хәл, уңышсызлык, күңелсезлек. *Тегеләй-болай килеп чыкса, бик тиз арт сабагын укытырлар.* Ф.Яруллин. *Юк, тегеләй-болай булган тәкъдирдә дә, минем өчен әлегә ул исән-сау. Ул яши, яшәсен.* В.Нуриев

3) Гайбәт, имеш-мимеш. *Төрле сүзләр йөри: имеш, Галинең башка хатыны бар икән, тегеләй-болай, фәләнфәсмәтән.* Р.Батулла

**ТЕГЕЛӘЙ-БОЛА́Й ИТҮ** *ф.* 1) Тегендә-монда, төрле якка хәрәкәтләндерү, төрлечә әйләндерү, боргалау. *Әйе, нәкъ бер җир буе ара калганда, Гаделия җиргә кадаклангандай кинәт туктап калды һәм тамак астындагы яулык төенен буш кулы белән бераз тегеләй-болай итте ахрысы, тамагын да кырды.* М.Мәһдиев

2) Төрле нәрсә эшләү; теләсә нәрсә эшләү. *Сандра аны [җәмкине] кулына алып кыскалап та, тегеләй-болай да итеп карады, аннары, Сафуанга күз сирпеп, тагын сөйкемле елмайды ---.* З.Мәхмүди

3) Берәр максатка ирешү өчен төрле ысуллар кулланып карау, нәрсә итсә дә итү. *Тиз генә мәхдүмне баудан төшереп, ясалма сулышлар алдырып, тегеләй-болай итеп коткарып калалар.* Р.Батулла. *Тракторчы тегесенбусын актара, тегеләй-болай итеп карый, ләкин һич кенә дә төзексезлекнең сәбәбен таба алмый.* Г.Рәхим

4) Аннан-моннан гына, җиңел генә карап яки бик тиз эшләп кую. *Мин әсәремне тегеләй-болай итеп кенә тәмамлый алмыйм. Мин аның нәкъ тормыштагыча булуына, ягъни реаль булуына ышанырга тиеш.* Г.Әпсәләмов

5) Тиешсез, тыелган, законсыз, әхлаксыз һ.б.ш. нәрсә эшләү. *Мораль шундый: сине яшь кыз вакытыңда теләсә нинди кабахәт тегеләй-болай итеп мыскылласа да, син безнең заманда барыбер бәхетле кеше булырга тиешсең.* Г.Әпсәләмов. *Бу канунга үзгәрешләр кертү тегеләй-болай итегез дигән канун түгел ---.* Н.Алан

**ТЕГЕЛӘ́Й-БОЛАЙ КИЛҮ** *ф. к.* **тегеләй-болай итү**. *Кара аны, әгәр Әминә белән тегеләй-болай килергә уйласаң...* Л.Лерон. *Бәяләр тегеләйболай килгәнче, язылырга ашыгыгыз, соңыннан үкенерлек булмасын!* Татарстан яшьләре

**ТЕГЕЛӘЙГӘ** *а.* **1.** Теге якка, билгеле юнәлештә, күрсәтелгән якка. – *Кая таба киттеләр? – Әнә тегеләйгә...* Т.Гыйззәт. *Мин аңа, чәнечкеле тимерчыбык борылып тегеләйгә киткән җирдә, почмакта, ермак бар шикелле, шуны тикшер, дигән идем.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Башка якка табан, икенче юнәлештә; кире якка. – *Син, әнә тегеләйгә карап, төпкә утырып тор, – диде. – Мин әйтмичә, болайга борылма, яме.* М.Хуҗин. *Болайга барып карыйбыз, тегеләйгә.* Р.Фәйзуллин

2) Башка юнәлеш биреп, башка юнәлешкә туры китереп, башка якка каратып. *Өстәл болай борылган, карават тегеләйгә.* Кәеф ничек?

**ТЕГЕЛӘЙГӘ́-БОЛАЙГА** *рәв.* Төрле юнәлештә, әле бер якка, әле икенче якка. *Ул да үзенең түгәрәк иллюминаторы каршысыннан тегеләйгә-болайга йөзеп йөргән балыкларны минем кебек күзәтә булыр.* Р.Рахман

**ТЕГЕЛӘЙМЕ-БОЛАЙМЫ** *рәв.* **1.** Ничек булса да, ничек тә, берәр ничек, берәр юл белән. *Ул алып килгән борчулар укытучыларның барысына да тегеләйме-болаймы кагылды.* М.Мәһдиев. *Шул рәвешле, җирнең төрле кыйтгаларындагы хәлләр белән тегеләймеболаймы танышканнар, әйләнә-тирә мохиткә, чынбарлыкка мөнәсәбәтләрен белдергәннәр.* Фән һәм тел

**2.** *кер. с. функ.* Һәрхәлдә, барыбер, ахыр чиктә, ничек кенә булмасын. *Ә кеше, тегеләйме-болаймы, гел бәхеткә омтылып яши.* И.Вәлиулла

**ТЕГЕЛӘЙРӘК** *с.* **1.** 1) Берәр ягы гадәттәгедән, нормадан начар, ким, кайтыш. *Хафиз бабай белән гәпләшүләр Бара авыр, китә озакка: Йөзгә җитеп, аннан узгангадыр, Тегеләйрәк бераз колакка.* Ш.Мөдәррис. *Күләме ун юлдан артса аз гына артыр. Эчтәлеге аннан да тегеләйрәк.* М.Гайнетдин

2) Берәр ягы гадәттәгедән, нормадан, башка кешедән артык, көчлерәк, яхшырак. *Ирләр бит, бер тотынсалар, балачагаңнан да тегеләйрәк!* Р.Гаязетдин

3) Авыр, кыен, мөшкел. *Х. Туфанның үзенең хәле дә Г.Ибраһимовныкыннан да «тегеләйрәк» була (Казаннан качып китәр көннәренә ярты еллар гына калган).* М.Гайнетдин

4) Сәер, гадәти булмаган, әллә нинди, ят. *Болар шул тегеләйрәк икән, дип уйлап куйды ул, тегеләйрәк дигәнен рәтләп үзе дә аңлап бетермәстән.* Ф.Хөсни

5) Акылга зәгыйфь, тулы түгел. *Бу карчык – иремнең әнисе, бераз аңы тегеләйрәк, әле яңа гына сары йорттан чыкты.* Х.Камалов. --- *шул мәлдә миемне бер гасабилы уй көйдереп узып китте: «Я Хода бәндәсе, тегеләйрәк түгелме соң син?»* Н.Гамбәр

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Башкача, башка рәвештә. *«Син, Габделҗәмил, тегеләйрәк итеп кара, болайрак эш кылып кара», – дип киңәш биргән картларның авызын тиз томалады.* М.Кәрим. *Дәү абзыйлар: «Ленин киманең койрыгын болайрак токтан иде, ә икенче берәү, бәлки, тегеләйрәк тотар», – диләр, үзара сак кына сөйләшкән чакларында.* Ә.Еники

2) Битәр, яманрак, артык. *Сак булыгыз, явыз тел! Эттән тегеләйрәк тешли...* Ш.Галиев. *Мин сугышны күз алдына китереп, үземне фронтка озатачакларын уйласам, Зәкия миннән дә тегеләйрәк уйлый торгандыр.* М.Харисов

3) Җитдирәк итеп, катгый рәвештә. *Ә син, Халикъ абзый, Нәсимә түтигә [мәсьәләне] тегеләйрәк, кабыргасы белән куй!* Ш.Камал

**ТЕГЕЛЕШ** *и.* Тегелү сыйфаты; тегелү рәвеше. *Шушындый чүпне алалармы? Күзегез чыкканмы әллә? Тегелеш ипсез, ефәге кыштырдамый... Чын кытай ефәгеннән тегелгәне унбиш тиен көмеш тора аның.* Ш.Усманов. *Затлы-затлы костюмнар, чалбарлар, пинҗәкләр, футболкалар, күлмәкләр тезелеп киткән. Нинди тегелеш, нинди тукыма, нинди размер кирәк, җаның нәрсә тели?* М.Кәбиров

**ТЕГЕЛМӘ** *и.* Бер төрле документ, кәгазь яки газет-журналларның бер төпкә беркетелгән җыелмасы. *Госпитальдәге кызыл почмакка Дамир журнал тегелмәләрен караштырырга кергән иде, кулына БАМ турында бер яңа китап эләкте.* С.Шәрипов. --- *без «Фикер», «әл-Ислах» гәзитләрен, «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт» журналлары тегелмәләрен кабат күздән кичердек.* З.Рәмиев

**ТЕГЕМ** *и. диал. к.* **тегү** II. *Тегем тегү дуга бөгү түгел ул.* Әйтем

**ТЕГЕМЧЕ** *и. диал. к.* **тегүче**

**ТЕГЕНДӘ** *а.* 1) Билгеле урында, күрсәтелгән җирдә. *Әнә тегендә бәйләм-бәйләм китаплар өелеп ята.* А.Тимергалин. *Әнә тегендә, өянке артында, муеннарына бинокль аскан ике малайны күрәсеңме?..* А.Гыймадиев

2) Икенче җирдә, башкарак урында. *Тегендә кәмитчеләр шау-шуы, монда гармун көенә карусель әйләнә, таган атыналар.* А.Тимергалин

3) Еректарак, арырак. *Мәктәп тегендә калды, ә нигә бакчасы монда?* А.Гыйләҗев

4) Күрсәтелгән урынга, шул якка табан, шул юнәлештә. *– Әйдә, тегендә минеке әле, – дип, өстәл янындагы тәрәзәгә ымлады Кәрләбикә.* Л.Закиров

5) Берәр куркыныч җирдә (җиргә), исемен әйтергә ярамаган, әйтәсе килмәгән җирдә (җиргә). *«Тегендә» киткәндә дә, үз өеңдә, караучыларың янда булганда, әкрен генә китеп барсаң иде ул...* Казан утлары

**ТЕГЕНДӘ́-МОНДА** *рәв.* 1) Төрле урында; теләсә кайда. *Тегендә-монда агач-такта кисәкләре ята, менә учак урыны да бар.* Г.Гыйльманов

2) Әле бер якка, әле икенче якка, бер яктан бер якка, арлы-бирле. *Чатанның каушап калудан бернинди карарга килә алмыйча, тегендә-монда чабышкан егетләрен чүпләделәр генә вертолёттан.* А.Хәсәнов. *Шыштыр, үз-үзен кая куярга белмичә, арлы-бирле, тегендә-монда йөренә.* Х.Ибраһим

3) Төрле якка, төрле урыннарга; теләсә кая. *Мин монда рәсми кәгазьләрне тутыру, төрле оешмалардан рөхсәт алу өчен тегендә-монда чабулар, кирәкле кешер яфракларына тиешле ришвәт турында сөйләмим.* Х.Ширмән. *Солтанъяр агай, мин сезне тегендә-монда таратуда мәгънә күрмим.* З.Мурсиев

4) Берәр җиргә, кая да булса. *Алай тегендә-монда барасым юк бугай.* З.Хәким

5) Кирәкмәгән, килешмәгән, тиеш булмаган җиргә. *Мин биргән акчаны тегендә-монда тотма, кирәккә генә тот.* З.Хәким. *Кеше өлешенә кереп, тегендә-монда барып кысылуны җене сөйми, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә, ачуланып, газабын ирештерүе бар.* Ф.Яхин

6) Анда-санда, кайбер җирдә генә, сирәк урыннарда

**ТЕГЕ́НДИ** *а.* **1.** 1) Икенче төрле; үзгә, башка, аерым. *Чаллы белән авыл арасын ничек үтәргә?! Автобуслар йөрми, тегенди машиналар утыртмый.* А.Гыйләҗев. *Атна арасында, тегенди көннәрдә сирәк-мирәк җәйләп ятучыларны искә алмаганда, [бу утрауларда] кеше-кара күренми диярлек.* Ф.Гарипова

2) Телгә алынган, мәзкүр, әйтеп үтелгән, баягы. *Акчаны ай саен таптык без, тик мин алтын кибетләрендә тегенди йөзекне күрмәдем.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* 1) *куч.* Сәер, әллә нинди, ят. *– Сөйләмим, барыбер ышанмыйсың син. Сезнең халык тегендирәк ул... Әкияткә боручан, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Ә тегенди, «Әйдәгез!» дип кычкыра-кычкыра, сәхнәдә концерт урынына дискотека куеп йөрүчеләрне карарга яратканнар килмидер, әлбәттә.* Тамаша

2) Әшәке, начар, килешмәгән; тәрбиясез, әхлаксыз. *Дөрес, синең кыланышларыңда тегенди яклар бар.* Г.Кутуй. *Тегенди авыруы бар икән, шуңа күрә өйләнә алмыйча йөри икән, диләр.* Р.Батулла

3) Шикле, шомлы, куркыныч; законсыз, җинаятьчел. *– Нindирәк адәм ул? – Күпне күргән кешегә охшый. --- – Тегенди кеше түгелме?* Х.Камалов

**ТЕГЕ́НДИ-МОНДЫЙ** *с.* 1) Әллә ни әйбәт булмаган, уртача гына сыйфатлы, урта кул (әйберләр тур.). *Өстәлдә самавыр җырлап утыра. Тегенди-мондый гына самавыр түгел – электәлектән бу йортның күрке булган җиз самавыр ул.* Р.Галиуллин

2) Вак-төяк, әһәмиятсез, ни җитте шул (кешеләр тур.). *Хәмидә апаның җырлавын тыңлап кайтам мин. Ә ул тегенди-мондый гына җырчы түгел.* В.Нуруллин. *--- үзеңнең бәяңне белгәнеңә ышаначаклар, шуннан тегенди-мондый шырды-бырдылар синең белән әңгәмә корып утырмас.* Э.Яһудин

3) Әллә нинди, бик сыйфатлы, бик әйбәт. *Әле бергә мәҗлесләрдә дә булганнары бар, шул Әлфәт әзерләтә бит иде аңа токмачлы аш, катык, итнең тегенди-мондыен. Аракының да пичәтлесен.* Р.Газиз

4) Теләсә нинди, һәртөрле, төрле-төрле. *Бу юл инде миңа бик таныш, әни белән тегенди-мондый вак-төяк сатарга гел шушында килә идек.* Ф.Яруллин. *Акыл үсешендә, тән-гәүдә торышында тегенди-мондый тайпылышлар булмасын өчен, бала белән туктаусыз шөгыльләнү, аны үзеңнән бер адымга да калдырмау кирәк.* К.Җәмит

5) Килешмәгән, кирәк булмаган; шикле, законсыз (эш-гамәл тур.). *Бикәнең тегенди-мондый эшләрен сизмәдеңме?* М.Галәү. *Малайлар да тегенди-мондый «һөнәрләрен» күрсәтә башлады.* М.Садыйков

6) Тәрбиясез, әдәпсез; әхлаксыз, бозык (кеше тур.). *Сез мине тегенди-мондый кызыкайдыр дип уйлый күрмәгез.* З.Хәким

**ТЕГЕРМӘН** *и.* 1) Игенне ярма яки он итеп тарттыру өчен махсус җайланма, машина. *Тегермән ташын күргәнең бармы синең?* А.Гыйләҗев. *--- булган орлыктан кара он тарттылар. Тегермән сабын әйләндерә-әйләндерә, Хәлимнең уч төбе ике кат сөялгә катты...* Г.Гыйльманов

2) Шундый җайланма урнаштырылган махсус бина. *Югыйсә авыл тулы балта остасы, ә авылда тегермән салучы юк.* В.Нуруллин. *Ашап алганнан соң, Яков Әмирне Чәрмәсән буена, тегермән янындагы кечерәк йорт күләгәсенә алып китте.* В.Имамов

3) Төп эше ашлык тарттыру булган хуҗалык предприятиесе. *Мин тегермән тотучы бер байда ялчылык итәм.* М.Галәү. *Унтугызынчы гасыр азагында парлы тегермән хуҗасы, сәүдәгәр хатын Макариха эрләүчелек берләшмәсе оештыра.* Кәеф ничек?

4) Гомумән, каты бөртекле нәрсәне дә булса ваклый торган җайланма, машина төре. *Борыч тегермәне*

5) *күч.* Пропеллеры яки әйләнә торган башка детале булган уенчык. *Бүген Әнвәр, атлап комлы юлдан, Ясап бара нәни тегермән.* Ш.Мөдәррис. *Без бу [язгы] көннәрдә кечкенә чокыр-чакырларга бәләкәй генә тегермәннәр, чарыклар корып уйныйбыз.* Г.Галиев

6) *күч.* Туктаусыз хәрәкәттә булган, көчле, котылгысыз күренеш турында.

*Ах, белсә-сизенсә икән кайнар йөрәкле егерме бер яшьлек егет нәкъ тагын егерме бер елдан Сталин корган үлем тегермәне аны да сытып ташлаячагын!* М.Шабаев

◊ **Тегермәне (әйбәт, шәп) тарту** Күп һәм комсызланып ашаучы кеше турында. *– Я, ничек, тётя Фая? – диде ул, малайлардан ишеткәнен кабатлап. – Егетләрнең тегермәне шәп тартамы?* М.Әмир. *Җитешеп калыгыз, Фәрдинең утыз ике ташлы тегермәне тарта башлады.* А.Гыйләҗев. **Тегермән тарттыру** *к.* **тегермән тарту**. *– Синең бөтен эшең телең белән тегермән тарттыру, – дигән, имеш, аңа Сәгыйдә апай.* Ә.Хәсәнов. **Тегермән тарту** 1) Артык күп сөйләшү; юк-бар сөйләү, ләчтит сату. *– Ярар, бушка тегермән тартмыйк әле, – диде Фарукҗан, бәхәсне туктатып.* Т.Әйди. *Килеп керүгә, Сабит Садыйкович сүзгә кушыла, һәм аның ару белмәс, тиктормас теле гел тегермән тартуда.* З.Хөсняр; 2) Йоклаганда гырылдау. *Авырулар кыска вакытлы тынычлыкка талганнар. Төрле көйгә, төрле тавышларга «тегермән тартканнары» ишетелә.* Г.Әпсәләмов. **Тегермән таш(лар)ыдай** *к.* **тегермән ташы кебек**. *Улай дәдә, кукрәгенә терәп, тегермән ташыдай икмәкне телемләп турый башлады.* Р.Батулла. **Тегермән ташы кадәр (хәтле)** 1) Зур һәм авыр; 2) Зур, җитди, олы куаныч яки көенеч турында. *Әйт инде, ахирәт, сөенечең чынлап та тегермән ташы хәтле зур булса, минә шул йөзегем сиңа булыр.* К.Тинчурин. *Башкаебызга тегермән ташы кадәр кайгы төште бит.* Х.Сарьян. **Тегермән ташы кебек (шикелле)** 1) Нык һәм эре тешләр турында. *Хәзрәтнең тешләре тегермән ташлары кеби иде.* Г.Тукай; 2) Зур һәм авыр. *Култык астында тегермән ташы кадәрле бодай күмәче; түшенә кадакка якын шикәр кыстырган; кесәсендә бер кисәк кер сабыны.* М.Хәсәнов. **Тегермәненә су кою** Эш-гамәле яки сүзе белән кемгәдер ярдәм итү, шуның яклы булу, билгеле як, партия, группа яки шәхес файдасына эшләү. *Ни генә эшләмәсен, һәр адымында ул шовинистлар тегермәненә су койды.* Г.Әпсәләмов. *Мылтыкны чиста йөртмәү – дошман тегермәненә су кою ул!* Х.Камалов

**ТЕГЕРМӘНЛЕ** *с.* Тегермәне булган. *Кучтавыл элек, имеш, бик зур авыл булган: әллә җиде мәчетле, өч тегермәнле, әллә өч мәчетле, җиде тегермәнле.* Н.Фәттах

**ТЕГЕРМӘНЧЕ** *и.* 1) Тегермән механизмын карап, эшләтеп торучы, гомумән тегермәндә эшләүче кеше. *Ике елдан соң, хәлләнеп, бүрәнә йорт торгызалар. Әткәйне авылдагы тегермәнгә тегермәнче итеп куялар.* С.Ибраһимова. *Ник ул егет өчен чәчеңне агартасың? Тиздән болай да уңмаган тегермәнче кебек ап-ак буласың бит инде.* Т.Галиуллин

2) *иск.* Тегермән хуҗасы, тегермән тотучы. *Татар тегермәнчесенең буасы китсә, ул моны су бабасыннан күрә һәм, аның күңелен йомшарту өчен, суга ярма белән тоз яисә тоздан гына торган төргәк ата.* Гали Рәхим. *Тамчы гына булган терекөмеш әкертен-әкертен буаны тишә дә, су, язгы ташкын шикелле, буаны эссе җәйдә агызып китә. Көндәш тегермәнчеләр берсенә берсе шундый этлек кылалар.* Уйлар дәрьясында

**ТЕГЕРМӘНЧЕЛЕК** *и.* Ашлык тарттыру эше; хуҗалыкның шуның белән шөгыльләнгән тармагы. *Халыкның тормыш-көнкүреше уртача, монда тегермәнчелек, тимерчелек, тегүчелек, чабата ясау, умартачылык белән шөгыльләнәләр.* Х.Садри. *Тарихи белешмәләргә караганда, XIX гасырның соңгы чирегендә Татарстанның Биектау районы Өбрә авылында да халык, тегермәнчелек, мич чыгару, тегүчелек белән бергә, чабата ясап сату белән шөгыльләнгән.* А.Тимергалин

**ТЕГЕ́Р-ТЕГЕР** *иярт.* Берәр нәрсә җиңел, тигез әйләнгәндә чыга торган тавышны белдерә. --- *хикмәтле әкиятләре белән сихерләгән ягымлы тавыш; --- тегер-тегер тәгәрәгән тәгәрмәчләрдә тирбәлә-тирбәлә, алдына башым салган килеш аның --- назлы җырларын тыңлап барулар – берсе дә кабат булмаячак.* Т.Гарипова

**ТЕГЕШ** *и. сир. к.* **тегем**. *Югарыда әйтелгән кызлардан күпләре тегеш, чигеш, нәкышь һөнәрләре үгрәндекләре кеби, өсләрендә улган киемнәре үз куллары илә тегелмеш вә эшләнмеш имеш.* Р.Фәхретдин

**ТЕГЕШТЕРҮ** *ф.* 1) Сирәк кенә, әледән-әле тегү. *Әниләре, хан заманыннан калган иске «Singer»ны теркелдәтеп, үзләренә, күрше-күләнгә кием-салым да тегештерә.* Н.Көбәш

2) Аннан-моннан гына тегү, теккән төсле итү. *Солдатлар кием-салымнарын чистарту һәм тегештерү, азрак ял итеп алу хәстәрен күрә башладылар.* И.Хуҗин. *Шул кичтә әтисе чын каеш бауны, тегештереп, авылның аргы очындагы хуҗаларына кире илтеп тапшырды.* Ф.Җамалетдинова

**Тегештереп кую** Тегештереп әзер итү. --- *сандалиларым да тәмам эштән чыкты. Базар мәйданыннан, эзләнеп, җеп, тимерчыбык кисәкләре табып, тегештереп куйдым.* Л.Гыймадиева

**ТЕГЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **тегү** I. *Халидәсе иптәш кызына күлмәк тегешергә китте.* М.Маликова

**ТЕГҮ** I *ф.* 1) Тукыма, күн, кәгазь-катыргы кебек йомшак юка нәрсәләрнең кырыйларын җеп белән беркетү, җөйләү. *Алып кайтканда, [шинель] миңа озын булгач кистермәкче идем, әни риза булмады, итәген, җиң очларын бөкләп тегеп кенә куйды.* В.Нуруллин

2) Махсус өлгеләр белән киселгән күн, тукыма һ.б.ш. материал кисәкләреннән кием-салым, тышлык, япма һ.б.ш.лар ясау. *Күлмәкләре күп иде Әкълимәнең. Әнисеннән калган иске «Зингер» машинасын келтердәтеп, аларны кыз үзе текте.* Г.Әдһәм. *Әтием Хәмидулла – оста тегүче, ирләргә каракүл бүрекләр, каракүл якалы затлы пәлтәләр текте.* Г.Галиева

3) Берәр нәрсәне тукыма, күн һ.б.ш. материал эченә салып, авызын җөй белән беркетү, шуның белән тышлау. --- *кия торган күлмәгенең итәгенә әллә ниткән догалар язган бөтиләр дә тегеп бактым – булмады, файдасы тимәде* ---. Гали Рәхим. *Гитлерчылар тарафыннан туган-үскән җирләреннән концлагерьларга куылган Европа кешеләре, юлда азыкка алмаштырырга яки берәр кара көнгә ярар дип, кием эчләренә*

*төрле кыйммәтле әйберләр тегеп куя торган булганнар.* Г.Әпсәләмов

4) Берәр өслеккә энә һәм җеп ярдәмендә нәрсәдер җөйләп беркетү, тагу, ябыштыру. *Ә үзе чемоданыннан ялтырап торган кара күн тужурка алып, аңа погоннар тегәргә кереште.* Х.Камалов. *Кителенең якасына ап-ак ситсы текте, бөтен булган җиз төймәләрен теш порошогы белән чистартты.* М.Мәһдиев

5) Нәрсәләрне дә булса җеп, бау, тимерчыбык һ.б.ш.лар ярдәмендә үзара беркетү. *Ул кәгазьләрдән Муса үзенә кечкенә генә куен дәфтәре текте һәм моңарчы шигырьләрен шунда язып барган иде.* Р.Мостафин

6) Берәр нәрсәне бик күп кадак белән тезмә рәвешендә кадаклап беркетеп кую, рәттән кадак кагып чыгу. *Тегү осталары, бәпкә утыртып, гәрничкә тотынган булганнар – гәрнич тегелмәгән. Гәрнич теккәч, калган эшләрен беләсең инде.* Х.Сарьян

7) *күч.* Ялган фактларга таянып нахак гаеп тагарга тырышу. *Рудныйны либераллыкта гаепләргә барча сылтаулар бар. Персональ эш «тегәргә» мөмкин.* Х.Камалов

**Тегә башлау** Тегәргә керешү. *Авылның киенергә, бизәнергә яратучы хатын-кызлары күлмәкне аңа биреп тектерә торган булдылар. Ул өс киемнәре дә тегә башлады.* М.Галәү. *Сугыш башланыр алдыннан, авылда тегү артеле ачылды. Солдат кием, бияләй, бүрек тегә башладылар.* М.Мәһдиев

**Тегә тору** Эзлекле рәвештә тегү. *Ә менә хәзер, мин үсә барган саен, әни аның итәген дә, җиңен дә түбәнрәк төшереп, озынайтып тегә тора.* В.Нуруллин

**Тегеп алу** Бераз вакыт тегү; тиз генә тегү

**Тегеп бетерү** Барысын да тегү; тегүне тәмамлау. *Һәркайсы үзенең кул эшен: кайсы тегеп бетерәсе күлмәген, кайсы чигелеп бетмәгән алъяпкычын, кайсы киерге белән келәм алып килгән.* М.Галәү. *Кар көртләрен түгеп бетердем. Һәм, кояшка бик охшыйсым килеп, Яңа күлмәк тегеп бетердем.* Ф.Җамалетдинова

**Тегеп бирү** Кемгәдер тегү. *Өстәмә яңа күлмәк кидерделәр, камзулымның төшкән төймәләрен тагып, сүтелгән урыннарын тегеп бирделәр.* Г.Бәширов. *Кат-кат өшкереп, әби бөти тегеп бирде.* А.Хәсәнов

**Тегеп җибәрү** Берәр башка эш-гамәл белән рәттән, өстәмә рәвештә тегү; көтмәгәндә тегәргә булу. *Алып җибәр, тегеп җибәр, күргәннәрнең күзе ут булсын!* Г.Бәширов

**Тегеп йөрү** Төрле вакытта, төрле җирдә тегү; шактый вакыт тегү белән шөгыльләнү. *Шәрип абзый да әти кебек яшьтән үк авыл арасында тегү тегеп йөргән.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тегеп карау** Тегү тәҗрибәсе ясау. *«Ак калфак» оешмасы әгъзалары һәрберсе, кулларына инә-җеп алып, калфак тегеп карадылар.* Казан утлары

**Тегеп кую** Алдан ук тегү; тегеп әзер хәлгә китерү. *Кара син аны ә, карап кына тоткан күлмәклекне кисеп, нәрсә тегеп куйган.* Р.Сәгъди. *--- ачык яшел төстәге япмалар, утә күренмәле яшел пәрдәләр тегеп куйгач, бу бүлмә дә хан сараена охшап калды.* А.Әхмәтгалиева

**Тегеп ташлау** Тиз-тиз тегү; аннан-моннан гына тегү. *Кая, китер әле, үзем ялт иттереп тегеп ташлыйм.* А.Алиш

**Тегеп тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта тегү; тегү эше белән мәшгуль булу. *Быелгы чыгышка махсус сәхнә киемнәрен тегеп тормадым.* Кәеф ничек?

**Тегеп утыру** Озаклап тегү. *Вафаның хатыны коймак пешерә, Зөһрә әби Сафага тула оек тегеп утыра.* М.Галәү. *Кичә кич вакыт узсынга тегеп утырган мендәр сүрүен бер читкә алып куйды да төшкән җыештыра башлады...* Г.Гыйльманов

**Тегеп чыгу** Барын да тегү; башыннан ахырына кадәр тегү. *Шау-гөр килеп, кичә без тегеп чыккан яңа жилетларны карыйлар.* Г.Бәширов. *Өйгә кайткач, җөйләрен тагын бер кат кулдан тегеп чыксаң, салмый киярго була рәхәтләнеп.* К.Кара

**Тегеп яту** *сөйл.* Тегү эшендә булу. *Көзгече Степан Муллиннан сорау алу беркетмәсен ишләре янына тегеп ятканда, бүлмәгә Касыйм килеп керде ---.* Т.Әйди

**ТЕГҮ** II *и.* Тегү (I) эше. *Кызлар тегү тегә, калфак чигә башлый – тормыш әкренләп көйләнә бара.* Т.Әйди. *Әти --- Мамадыш якларында тегү тегеп йөргәндә, әниемне туган авылыннан бик яшьли аерып алып киткән бит.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТЕГҮ** III *ф. иск.* 1) Кадау, чәнчү

2) Нәрсәне дә булса вертикаль хәлдә урнаштыру, утырту, кагып, кадап кую. *Талантыңа җилкән тек, җил булмаса ишкәк ал!* Мәкаль. *Туган җиргә туың тек!* Мәкаль

3) Терәү, таяндыру, бастырып кую. *[Морат] утырган да салкын таш өстенә, Терсәкләрен теккән тезенә.* Ф.Бурнаш

**ТЕГҮ** IV *ф. к.* **текәү**. *Ничөн суга сузыласың, Тал чыбыккай, интегеп; Ялварасың, борыласың, Тилмерәсең, өзеләсең, Аккан суга күз тегеп.* Дәрдемәнд. *Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә, Яшь һилал урынында анда тулган айның яктысы.* Г.Тукай

**Тегеп калу** Тегелгән хәлен саклау. *Күзләремне мин тегеп калдым, тегеп калдым аңа. Лалә-гөлләрне җыеп калдым, өзеп салдым аңа.* Р.Гаташ

**Тегеп тору** Даими теккән булу. *Кара син, минем үз урыныма мулла булыр дип, күз тегеп торган балам бүген шул ---.* Ф.Әмирхан

**ТЕГЎ-ЧӘНЧҮ** *и. к.* **тегү-чигү**. *Газизә бер читтәрәк нәрсәдер тегүчәнчү белән утыра, карчык анасы самавыр куеп маташа иде.* Ш.Камал

**ТЕГҮЧЕ** *и.* Тегү эше остасы; башлыча кием-салым тегү белән шөгыльләнүче һөнәрче; кием тегү тармагында эшләүче кеше; җөйче. *Утә ачык чырайлы сүзчән кешеләр булып чыктылар болар, ире Бишбалтадагы кайсыдыр бер әртилдә тегүче булып эшли икән ---.* Ф.Хөсни. *Ә элек өй саен оста, урам саен тимерче, ике йортның берсендә тегүче була торган иде.* Р.Вәлиев

**ТЕГҮЧЕЛЕК** *и.* Тегүче һөнәре; хуҗалыкның кием-салым һ.б.ш. тегү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Яши белсәң, тегүчелек хәзер – иң шәп һөнәр.* Ф.Яруллин

**ТЕГЎ-ЧИГҮ** *җый. и.* Тегү, чигү һ.б.ш. кул эшләре. *Минем әнием –*

*тегү-чигү эшенә оста, өй эшләренә бик һәвәс, йомшак күңелле, басынкы кеше.* Ф.Сафин. --- *кияүдәге апасының уңганлыкларын белсәң, тагын да шаклар катарсың: тегү-чигү белән ярты шәһәр халкы шул апасына йөри, үзе чибәр, үзе булган.* Г.Гомәр

**ТЕЗ** *и.* 1) Балтырның калын сөяге белән бот сөяген тоташтырган буын. *Аның хәле бетте, дәрманы таралып, тез буыннары өзлекте.* А.Хәлим. *Ахырда Микола абый бөтенләй юмартланып китә. «Ярар, үземә көтүдә бер дигәннәре үсеп килә», – дип, тезенә сугып куя.* А.Хәсәнов

2) Хайваннарның алгы аякларындагы урта буын һәм шуның алгы ягы

3) Гомумән, гәүдәнең шул турысы. *Көнләүчеләр – гүя астан чаккан чаян... Тезеңә бәрсәләр, кулларыңа таян!* Р.Фәйзуллин. *Сынмады микән? Тез тирәсен баскалап карый.* Г.Тарханова

4) Чалбар-ыштанның яки оекның шул турысы. *Сырган чалбар тездән югарырак яулык белән кысып бәйләнгән иде.* Г.Әпсәләмов. *Озын буй, өстә әллә кайчаннан искеләр арасында аунаган аксыл плащ, тезе сизрәгән лавсан чалбар.* А.Гыйләҗев

5) Утырган кешенең итәге, ал. *Бала тез өстендә сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә, дип хак әйткәннәр.* Х.Камалов. *Бу төнге маҗараларны нечкәләп сөйләп бирергә, барыннан да бигрәк Дарья Петровнаның тезендә яткан сабыйның газапларын тасвирларга минем каләмемнең көче җитми.* М.Маликова

◊ **Тез астына салу** Тулысынча буйсындыру, баш идерү; яулап алу. *Икесе дә яу гыйлемен бик шәп үзләштергән, кала артыннан калаларны тез астына салып, Сәлим солтанның данын арттыралар.* В.Имамов. **Тез астына сугу** Кисәк, көтелмәгән яктан зыян китерү, бик авыр хәлгә кую, бик зур кыенлык тудыру; кайгы-хәсрәткә салу. *Ул шулай әкрен генә кешедән көлергә өйрәнде. Әлегәчә аның һәр кыланышын кичерә килделәр. Әлфия генә тез астына сукты, каһәр!* Н.Гыйматдинова. *Тәэминаттагы өзеклек әллә нинди шөһрәтле төзелешләрнең дә тез астына суга.* Ф.Абдуллин. **Тез буыны бушау** Кисәк хәл китү, хәлсезләнү; куркып калу, каушау. *Керүем булды, тез буыны йомшарды да китте бит, малай. Соңыннан әйтүләренә караганда, ап-ак кәгазь кебек агарганмын...* Ф.Баттал. **Тез буыны йомшау** *к.* **тез буыны бушау**. *Ә без сабак алыйк Үткәндәге хәтәр хәлләрдән, Тез буыны ләкин йомшамасын Мәскәү әйткән һәрбер хәбәрдән.* Ә.Рәшит. **Тез буыны калтырау** *к.* **тез буыны бушау**. *Сул яктагы бушлыкны уйлап, хатынның тәне чымырдап, тез буыннары калтырап китте.* Р.Габделхакова. **Тез буынын калтырату** Куркыту, өркетү. *Әмма моны аңлау аның тез буынын калтыратмады, киресенчә, күңеленә хөрлек, көч өстәде.* Р.Кәрами. **Тез буыны сыек** 1) Физик яктан әллә ни көчле булмаган. *Тез буыны гына сыек булырмы? Балык белән ерак китә алмассың.* Р.Кәрами; 2) Йомшак табигатьле, ихтыяр көче булмаган, көчсез характерлы. *Кантарлы талант тез буыны сыек шәхесне басып сыта.* Р.Батулла. **Тез буыны нык** 1) Физик яктан көчле; 2) Кыю табигатьле, ихтыяры, характеры көчле. *Менә кайда сынала солдат, тез буыны ныкмы-түгелме икәне ачыклана.* Казан утлары. **Тез йөгендерү** *к.* **тез чүктерү**. *Ә тора-бара хан була һәм ярты Җир шарын яулый, хисапсыз күп халыкларның патшаларын үзенә тез йөгендерә.* Р.Зарипов. **Тез йөгенү** *к.* **тез чүгү**. *Кошчак олан билбавын чишеп, тез йөгенеп, кынысы-ние белән хәнҗәрен казыйга сузды.* Р.Батулла. *Икенчеләй әйтсәк, гамәлдәге имла кагыйдәләре бер телнең икенчесенә тез йөгенүен, коллык итүен тәэмин итә.* З.Мирзануров. **Тез чәнчеп утыру** Аякларны тездән бөкләп, тезләр өскә карап торырлык итеп гәүдәгә якын китереп утыру. *Карт, күз алдына шушы күренешләрне китергәч, мендәрдән ихтыярсыз башын ала да тезләрен чәнчеп торып утыра.* Г.Галиев. *Төрле ризык тезелгән ашъяулык тирәсенә тез чәнчеп утырдылар.* Л.Зөлкарнәй. **Тез чүгү** 1) Берәр нәрсәгә ихтирам күрсәтеп, мәсәлән, төрле йола һәм ритуал барышында, тезнең берсе яки икесе белән дә җиргә басу, таяну. *Хөрмәтләп, тәгъзыйм итеп зур кояшны, Тез чүгә, итагатен гарыз итә.* Н.Думави. *Ир кеше фәкать хәрби байрак алдында гына тез чүгә...* Р.Кәрами; 2) Кемнең дә булса берәр сыйфаты алдында ихтирамын белдерү, аның өстенлеген тану, шуны күрсәтү. *Бу бөек музыка, аһәң алдында йөз еллык юкәләр дә тез чүгәргә әзер.* А.Хәсәнов. *Мин килдем, Гәнҗәви, каршыңа, Тез чүгәм һәм баш иям талантыңа. Кил, зинһар, кылсана син бер дога, Бирсен Ходаем иркенлек халкыма.* В.Ильясов; 3) Тулысынча буйсыну, баш ию, каршылык күрсәтүдән туктау. *Үз халкы белән аралашудан курка, тез чүгеп булса да, яулап алучылар белән ярашып яшәргә тырыша.* М.Юныс; 4) Искереп, тәбәнәкләнү, авышу, җиргә сеңү (төрле корылмалар тур). --- *дистә еллар буе кешесез тора-тора тез чүгә башлаган каралтыкуралар сипләнә, яңартыла, кыскасы, яшәрлек хәлгә китерелә.* З.Хөснияр; 5) Кыенлыкларга каршы тора алмау, нык бирешү, артка китү. *Кем-кем, ләкин Калинин исемендәге колхоз тез чүгәргә тиеш түгел иде.* Кызыл таң. **Тез чүктерү** Тулысынча буйсындыру, баш идерү; яулап алу. *Мәшрикътагы ничә ханны, тау солтаннарын тез чүктергән, алтын тәхет ханнарын пыран-заран китергән әмир Тимернең моңарчы үзенә буйсынудан баш тарткан әсирләрне күргәне булмады.* Р.Батулла. *Минем әле Көнбатышта кичектергесез бурычларым бихисап. Литваны, Польшаны, Ливонияне, Курляндияне тез чүктерәсем бар.* М.Әмирханов

**ТЕ́З БАШЫ** *и.* 1) Аякларны бөкләгәч, утыргач, чүгәләгәч, почмак булып чыгып торган тез буыны. *Әмма ул, очлы бүреген тез башына элеп, стена буена утыра да иң элек тәмәке соранырга тотына иде ---.* Г.Бәширов. *Кияү пальтосын чишеп җибәрде, бүреген салып тез башына киертте.* М.Мәһдиев

2) *к.* **тез капкачы**. *Снаряд кыйпылчыгы Хисмәтнең тез башын челпәрәмә китерде, иптәшләре белән йөгереп барган Хисмәт нарат астындагы чокырга гөрселдәп барып төште.* М.Мәһдиев. *Икенчедән, келәткә иген ташыганда,*

*бусагага абынып, әниең тез башын җәрәхәтләде, әле дә юньләп аягына баса алмый...* Т.Әйди

3) Гәүдәнең, тәннең тез буыны турысы, шул тирәсе. *Әхмәтнең өстендә әллә кайчан уңып беткән иске киндер күлмәк, ыштан ертыгыннан тез башы күренеп тора.* Г.Бәширов

4) Чалбар яки оекның тез турысындагы өлеше. *Әбүзәр Таймасның эре чәчәкләр төшкән күлмәк кигәнен, чалбарының тез башына ямау урынына кесә салынган булуын, чәченең дә, кара булмыйча, сары икәнлеген әйтте.* А.Тимергалин. *Фатыйма аңа карап сокланып туя алмады, тез башы ямалган иске колготкилы кыздан шундый ханбикә чыгар дип кем уйлаган.* З.Мурсиев

5) Тез өсте, итәк, алын. *Аннан соң, ханнар, әмирләр, мирзаларның өйдә чакта да тез башына бала утыртып сөйгән чаклары бик сирәк була.* Р.Батулла. *Өйләрендә оныкларын тез башына утыртып сөю хисләре дә калмады микәнни?* Ф.Баттал

**ТЕЗГЕН** *и.* 1) Ике очыннан кирәк якка тартып атны җитәкләп йөртү өчен кулланыла торган, авызлыкка беркетелгән тар каеш, йөгәннең бер өлеше. *Ул [ишан], итәгенең сул ягын кайтарып, атның тезгененнән тотты да, арбасына илтеп бәйләү өчен, ялчыга биреп җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Яугирләр, үкчәләре белән атларының корсагына дөп-дөп тибеп, шатыр-шотыр тезген тартып, атларының башын әле бер, әле икенче якка каералар.* Р.Батулла

2) *күч.* Җитәкчелек, идарә итү чарасы. *Сталинның гәүдәсе суынып-суынмас, алар арасында инде җитәкчелек тезгенен алу яки кемгә бирү турында яшерен уйлану, план кору, берберсеннән шикләнү һәм курку мотлак башланган да булгандыр...* Ә.Еники

◊ **Тезген бушау** Җитәкчелектә таләпчәнлек кимү, идарә итүдә, контрольдә катгыйлык бетү. *Ә тезген бушау һич көтмәгәндә, бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыкты.* Х.Мөдәррисова. **Тезгендә тоту** Ихтыярга буйсындыру, басып тору, тыю. *Һич тотар хәл юк күңелнең тезгенен.* Ш.Бабич. *Ул үзенең эшгамәлләрен тезгендә тота алмый башлады.* И.Нәбиуллина. **Тезгенне бушату** Йомшаклык күрсәтү, таләпчәнлекне киметү. *Хисләнеп тезгенне бушатмыйк әле.* Н.Гыйматдинова. *Мин юкта эш тезгенен бушатмагансың!* Х.Камалов. **Тезгенне кулдан ычкындыру** Буйсындыра, тыеп я тыелып тора алмау; идарә итү көчен югалту, җитәкчелектән язу. *Кыскасы, Зөфәр бервакытта да, хатын кирәк бит, дип башын җуймады, нәфес тезгенен кулыннан ычкындырмады, ара-тирә берәрсе белән якын бәйләнешкә кереп киткән чакларда да, исеменә яки эшенә куркыныч туа башласа, шунда ук тыела белде һәм чигенә алды...* Ә.Еники. **Тезгенне кыска тоту** Таләпчәнлек күрсәтү, кырыс мөгамәлә итү. *Юк шул, директор алай эшләми, әрсезләнүчеләрнең дә тезгенен кыска тота.* К.Миңлебаев. *Гомергә ашыккан, гомергә бушамаган әнисе бу юлы да тезгенне кыска тотты.* Т.Гарипова. **Тезгенне үз кулына алу** Җитәкчелекне үз өстенә йөкләү, үзе идарә итә башлау. *Галләм абзыйдан яшь булса да, Солтангир Габсалихович тезгенне үз кулына алды.* Р.Кәрами

**ТЕЗГЕНЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **тезгенләү**. *Тезгенләнгән атлар сыман, Таллар башларын чайкый.* Ш.Галиев

**ТЕЗГЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Йөгәнгә тезген беркетү. *Бурлы кашка атымның Тезгенләдем йөгәнен.* Җыр

2) Атка тезгенле йөгән кидерү, йөгәнләү. *Әмма Аксай хуҗасы атны тезгенләп араннан чыгара башлауга, гипнозга бирелеп хәрәкәтсез калгандай тоелган Фәрхәд кинәт айнып китте һәм аларга каршы ташланды.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Тыю, басып тору, үз ихтыярына буйсындырып, эш-гамәлләрне чикләү. *Балаларны бөтенләй тезгенсез, караусыз җибәрергә ярамаган кебек, бөтенләй тезгенләп, тышаулап, бикләп тоту да ярамый.* Р.Фәхретдин. *--- дөрес, Шанаев бәлачелрәк кеше, ләкин Дорды аны тезгенләп тота белә.* Ә.Еники

**Тезгенләп алу** Тиз арада, тиз генә тезгенләү. *Бер мәлгә тәмам башларны әйләндереп, күз алларымны караңгылатып җибәрде, ләкин шунда Сәкинәм күз алдыма килеп басты, һәм мин, айнып китеп, үземне тезгенләп алдым.* В.Нуруллин

**Тезгенләп бетерү** Ахырга кадәр тезгенләү; барысын да тезгенләү

**Тезгенләп кую** Алдан тезгенләү; тезгенләнгән хәлгә китерү. *Яңа чирәм белән бергә кояш нурларына үрелеп сөенгән малайны беркем бәйләп, тезгенләп куя алмый.* Ф.Мөслимова

**Тезгенләп тору** Әле, хәзерге вакытта тезгенләү; тезгенләгән хәлдә тоту

**ТЕЗГЕНЛЕ** *с.* 1) Тезгене булган. *Сылап, сыйпап, ялыннан, тамак астыннан иркәләп, аның башына озын, калын тезгенле каеш нуктаны кидерделәр, ике катлаулы сакалдырыкны каты тартып бәйләделәр.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Буйсындырылган

**ТЕЗГЕНЛЕК** *и.* Тезген ясарга яраклы каеш яки б.ш. материал

**ТЕЗГЕНСЕЗ** *с.* **1.** 1) Тезгене булмаган, тезген тагылмаган. *Бер сакчы, бернечә йөгән күтәреп кереп, хан каршына чүгеп, аларның тезгенсез икәнлекләрен күрсәтә.* Н.Исәнбәт

2) *күч.* Тәртипкә, әдәп-әхлак кагыйдәләренә буйсынмаган, үзен тыйнаксыз тоткан. *Комрат бинең тезгенсез хатынының да мәсхәрә булганы халыкка таралып, бикәч үзенә хәнҗәр кадаган.* Р.Батулла

3) *күч.* Чикләүләрне белми торган, бернинди киртәләргә дә сыймаган. *Су дәрьясы чиксезлегендә гизгәндә, тезгенсез хыял гына мондый матурлыкны иҗат итә алгандыр.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тезгеннән башка, тезген такмыйча. *Горький русы Василий ничектер үзеннән-үзе башрак булып танылып өлгергән иде инде, шуңа күрә ул гел алдан бара, ә Хәким белән Талип, тезгенсез җибәргән атлар шикелле, аңардан калыбрак атлыйлар.* Ә.Еники

2) *күч.* Тәртипкә, әдәп-әхлак кагыйдәләренә буйсынмыйча, үзен тыйнаксыз тотып. *Кеше көлдерәм дигәч тә, алай тезгенсез кыланырга ярамый.* С.Кудаш

3) *күч.* Чикләүләр белмичә, киртәләргә карамыйча. *Аһ, кайда син, яшьлегемнең тезгенсез чапкан чагы.* И.Юзеев

**ТЕЗГЕНСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Эш-гамәлләрдә, холык-фигыльдә, сөйләгән сүздә

әдәп-әхлак кагыйдәләренә сыймау, тәртипсезләнү. *Тезгенсезләнеп, авызлык тешләп дигәндәй пырдымсызланган егетләр казый хозурындагы шәкертләр сыман шым булдылар.* Б.Камалов. *Иң тезгенсезләнеп ачуланганында да автор патша атамасын хәтта телгә алмый, гүя аңа бернинди җаваплылык йөкләнмәгән.* М.Гайнетдин

**Тезгенсезләнә бару** Торган саен ныграк тезгенсезләнү

**Тезгенсезләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта тезгенсезләнү

**ТЕЗГЕНСЕЗЛЕК** *и.* 1) Тезген киделмәгән булу

2) *күч.* Тотнаксызлык, әдәпсезлек. *Тезгенсезлек гармонияне боза, изге күргән семья тормышыннан бернәрсә дә калдырмый.* Г.Әпсәләмов. *Монда да төп сәбәп динсезлеккә бәйләнгән: яшьләрнең әхлакый тезгенсезлеге, гаиләдә бер-береңә итагатьсезлек, эчкечелек һәм башка шуның ишеләр.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**ТЕЗГЕЧ** *и.* Тотылган балыкларны саңагы аша үткәреп элә торган шнур яки чыбыкча. *Тезгеч ясап, аңа киертеп суга салдым. Трофей бер килолы корбан балыгы булып чыкты.* Ватаным Татарстан

**ТЕЗГЕЧЛӘ́Ү** *ф.* Бер тезгечкә элеп тезү

**Тезгечләп кую** Алдан тезгечләү; тезгечкә элгән хәлгә китерү

**Тезгечләп чыгу** Барысын да башыннан ахырына кадәр тезгечләү

**ТЕЗДӘН** *рәв.* 1) Чама белән тез тиңентен, тез турысыннан, тез биеклегендә. *Тездән пычракка батып, туңып кайтып кергәннәр.* Х.Садри. *Нуретдин абзый --- бер ферманың тездән яшел үлән эчендә йөрүче зур, кызыл чуар сыерларын төшергән буяулы плакатка карап, сүзен дәвам иттерде.* Ә.Еники

2) Тез турысына җиткәнче, тез турысына кадәр. *Өй кыегыннан агып, ләгәнгә җыелган яңгыр суында тездән пычракка баткан итекләремне юам, чоландагы янәшә кадакка юеш кожанымны җәеп eләм.* Л.Ихсанова. *Тездән суга кереп, чабак, таштый, этләй маймычлары белән уйнады.* Г.Гыйльманов

**ТЕЗДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тезү**. *Чирүне ул җәя рәвешендә тездерде һәм ерак булмаган Бачман баһадир гаскәренә таба кузгалырга боерды.* М.Хәбибуллин

**ТЕЗЕ** *и. иск.* Күп катлы муенса. *Анасында кызы кайгысы, Кызында тезе кайгысы.* Мәкаль

**ТЕЗЕЛЕШ** *и.* 1) Тезелү эше, тезелү гамәле. *Гүя шулай таралыплар бетеп, Бу бит кабат кайтып тезелеш.* Ф.Яхин

2) Тезелгән саф, строй; тезем; тезелү рәвеше. *Дүртәр-дүртәр булып сафланган җайдаклар тезелеше*

**ТЕЗЕЛЕШҮ** *ф.* Бер-бер артлы тезелү, рәт-рәт булып урнашу. *Бүреләр тагын кузгалдылар, каршыга килә башладылар. Бу юлы тезелешеп түгел, һәрберсе үз юлы белән килә иде.* Г.Гыйльманов

**Тезелешеп бетү** Бөтенесе дә тезелешү, ахырга кадәр тезелешү

**Тезелешеп килү** Берсе артыннан берсе тезелешкән булу. *Ә, юк икән, онытылып калган яшьлеге түгел, очар кошлар кебек тезелешеп килгән сабый чаклары, әтисенә ияреп йөргән ялана-яклы кызчык вакытлары икән!* Ф.Яхин

**Тезелешеп китү** Бер-бер артлы тезелешкән хәлдә булу. *Иң элек, урам буйлап ике яклап тезелешеп киткән йортларның һәммәсе дә яшел төскә буялган булу җәлеп итте аның карашын.* Р.Мөхәммәдиев

**Тезелешеп тору** Әле, хәзер яки гомумән тезелешкән хәлдә булу. *Монда вагоннар кыр казлары төсле тезелешеп торалар.* А.Алиш. *Дивардагы игъланнар тактасында Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахун кебек язучыларның исемнәре тезелешеп тора.* Р.Батулла

**ТЕЗЕЛМӘ** *с. мат.* Аерым саннардан тезелгән. *Тезелмә саннар*

**ТЕЗЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тезү** I. *Мизгелләр хәрефләр, сүзләр булып тезелә.* А.Мансуров

2) Җыелып тору, җыелышу, бергә урнашу. *Җитмәсә, өйалды каршына тезелгән хатын-кызлар янынннан узып киткәндә, Мортазин елан ысылдаганга охшашрак тавышлар да ишеткәндәй булды.* В.Имамов

3) Нинди дә булса бер тәртип белән урнашу. *Җирдәге торна ишегалдын бетереп чабып йөри-йөри дә, җан-фәрманга талпынып, һавага күтәрелә, --- почмак ясап тезелгән торналарга таба юнәлә...* А.Тимергалин. *Утыз өч җайдак, бер сызыкка тезелеп, чабыш юлына чыгарга әзерләнгән.* Г.Гыйльманов

**Тезелә бару** Әкренләп, эзлекле рәвештә тезелү. *Әнә инде төрле төстәге гәрәбәләр белән чәчәкләп-нәкышьләп тышланган биналар да бер-бер артлы тезелә бара.* Ф.Баттал

**Тезелә башлау** Тезелергә керешү. *Орышка чыгарга алгысыган яшь яугирләр, угланнар капка саен тезелә башлады.* Р.Батулла. *Базарга илтә торган киң юлның ике ягын биләп, җиңел машиналар тезелә башлады.* К.Кара

**Тезелеп бару** Берсе артыннан берсе тезелү. *Бер җепкә тезелеп барган энҗе бөртекләре кебек саф, хәйләсез сүзләре Хәлимнең күңелендәге бозларны эретерлек иде.* Ф.Яхин. *--- барысы да шагыйрә каләменнән энҗе бөртекләредәй сафлык-нәфислек белән шигырь юлларына ифрат иплe тезелеп бара.* К.Тимбикова

**Тезелеп бетү** Барысы да тезелү. *Кәгазь өстендә йортлар тезелеп бетеп, чып-чын Ташлыяр авылы абайлангач, ул үз эшенә сокланып торды.* Р.Вәлиев

**Тезелеп китү** Берсе артыннан берсе тезелгән хәлдә булу, тезелгән булып күренү. *Стенада әллә ничә төрле пычкы, өтерге, эреле-ваклы бораулар тезелеп киткән.* Г.Бәширов. *Янәшә тезелеп киткән яңа йортлар тирәсендә ятимләнеп утырган нәзек каеннарны да, киселмичә калып, бәхетле кукрайган тупылларны да күрергә мөмкин.* А.Әхмәтгалиева

**Тезелеп тору** Әле, хәзер тезелү; тезелгән хәлдә булу. *Маруся үзенең тезелеп торган ак тешләрен күрсәтеп елмайды.* Ә.Айдар. *Шунда ук офицер һәм солдатлар сафка тезелеп тора.* В.Имамов

**ТЕЗЕМ** *и.* 1) Бер-бер артлы торган әйберләр, кешеләр һ.б.ш.ның тезелүеннән хасил булган җыйма күплек; тезмә. *Сөем тутай белән ахирәтләр --- атасының көтебханәсен тәртип итеп, --- һәр китапның кайсы бүлмәдә, кайсы теземдә, кайсы киштәдә, кайсы урында икәнен бик тиз табар өчен,*

*аерым җәдвәл төзеп куйды.* Р.Батулла. *Теземнең иң артында менә калам, менә калам дип очкан ана үрдәк төркемнән түбәнәя башлады, тупыл очларына тиеп үтте, агачлар арасында күздән югалды.* Л.Зөлкарнәй

2) Буразна рәте. *Эшләр кызды һаман. Тиземнәргә оялап-оялап орлык күмелде.* Ш.Мөдәррис

3) Иген яки печән пакусы. *Аста, гәрәбә төскә манчылган иген кырында, комбайн арышны тиземнәргә сала.* К.Тәхау. *Бервакыт авыл хатыннары кырда чалгы белән печән чаба, ә мәктәп балалары кояш кызуында кипкән тиземнәрне әйләндерә иде.* Н.Гыйматдинова

4) *лингв.* Бер-берсенә бәйләнгән яки берәр аерым сүз яки җөмлә белән берләштерелгән җөмләләрнең зур төркеме. *Биредә тезем турында да беренче тапкыр буларак мәгълүмат бирелә һәм ул «катлаулы кушма җөмләнең киңәйтелгән төре» дип аңлатыла.* Г.Нәбиуллина

5) *әд.* Шигъри әсәр, шигырь. *Кайчак шигъри әсәр диясе урынга тезем белән язылган әсәр диюне ишетергә туры килә.* Татар әдәбияты

**ТЕЗЕМЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **теземләү**

2) Теземнәр барлыкка килү. *Кыр казлары теземләнеп оча*

**ТЕЗЕМЛӘ́Ү** *ф.* Теземгә салу, тезем ясау. *Хәле кадәренчә кайсы баш яулыгы, кем кулъяулык, кем күлмәклек тукыма кисемтәсе, тастымал, сөлге чыгара, иң ару дигән бүләкләр колгага бәйләнә, тыйнагракларыкабык арбага теземләп салына.* Р.Зарипов. *Кибәкне алмаш арбаларга җыялар, ә саламны, бөтен килеш, тезем ясагыч ярдәмендә, теземләп салып чыгалар.* Урып җыю машиналары

**Теземләп бетерү** Барысын да беткәнче теземләү

**Теземләп кую** Алдан яки тиз арада теземләү

**Теземли бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы теземләү

**ТЕЗЕМЛЕ** *с.* 1) Теземнәрдән торган; теземгә салынган. *Тиземле чабыннар*

2) Берсе янында берсе үсә, арта барган аерма нигезендә тезелеп урнашкан, берсе артыннан берсе килә торган. *Шуның өчен дә, борынгыга киткән саен, табышмакларның форма ягыннан озынрак һәм теземлерәк булып, мәгънә сурәтчәләре ягыннан да катлаулырак була барганын күрәбез.* Н.Исәнбәт

**ТЕЗЕМЛЕЛЕК** *и.* Теземле булу, эзлеклелек. *Сикереш – теземлелек һәм эзлеклелекнең бердәмлегеннән гыйбарәт, сикерешне теземлелеккә яки эзлеклелеккә каршы куярга ярамый.* М.Абдрахманов

**ТЕЗЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **тезү**. *Урагын да урды Габделхәй, [әтисенә] кибән төбенә көлтәсен дә тезеште.* М.Хуҗин

**ТЕ́ЗИС** *и. гр.* 1) Исбат ителә, каралуга куела торган берәр фикер, хөкем. *Заманында ул [Атилла Расих], безнең әдәбиятта уңай герой берниндитапсыз, идеал булырга тиеш, дигән тезис та күтәреп чыга.* Р.Зарипова. --- *базар шартларында икътисади мөнәсәбәтләр үзеннән-үзе көйләнә, дигән тезис нигезсез.* И.Фазлетдинов

2) Доклад, нотык яки иншаның төп фикерләре язылган кыскача аңлатма. --- *әмма докладчы фактларга нигезләнеп үз сүзләрен дәлилләми, ә фәкать коры тезис белән чикләнә ---.* Г.Ибраһимов. *Ул [Габдрәфыйк Габдрахман улы] анда [куен дәфтәрендә] кемнең нәрсә сөйләгәнен тезис рәвешендә теркәп барган, шунда ук икенче биттә кайту белән колхозда бу уңайдан ниләр башкарырга кирәклеген язган.* Кызыл таң

**ТЕ́З КАПКАЧЫ** *и.* Балтырның калын сөяге белән бот сөяген тоташтырган буынны алгы яктан каплап тора торган түгәрәк җәлпәк сөяк. --- *ялт итеп тегене баш аркылы чөйим дип җирдән кубарып алуым булды, сул аягымның тез капкачы урыныннан купты.* А.Гыйләҗев. *Ун яшьлек чакта, кыш көне утын төялгән ат чанасы әйләнеп китеп, абыйсы чана астында калган, һәм, ике бүрәнә арасына кысылып, сул аягының тез капкачы чәрпәләнгән.* З.Зәйнуллин

**ТЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тезләнү**. *Зөфәр Мөнирнең кулын каерып тезләндерә.* Аманулла. *Аны шундук бәйләнгән җиреннән чишеп, атаман алдына китереп тезләндерделәр.* Р.Сәгъди

2) *куч.* Буйсындыру, буйсынырга мәҗбүр итү. *Кайдадыр матбугатны тезләндерергә, гаярь, туры сүзле журналистларны эзәрлекләргә тартынмаган бер заманда (андый мисаллар күп, хәтерегезгә генә төшерегез) Татарстанда ай саен диярлек яңа басмалар «борын төртә».* Р.Фәйзуллин. *Гитлерның, суыклар башланганчы Мәскәүне алып, Рәсәйне тезләндерергә, дигән планы барып чыкмагач, һөҗүм Мәскәү бусагасында канга гарык булып туктап калган иде.* З.Зәйнуллин

**Тезләндерә бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы тезләндерү

**Тезләндереп алу** Бер тапкыр, кыска вакытка тезләндерү; тәмам, тулысынча тезләндерү; тезләнергә мәҗбүр итү

**Тезләндереп кую** Тезләнгән хәлгә китерү

**ТЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Җиргә, өслеккә тез белән таяну, тездә тору. *Чатырга җитәрәк Көнбаш атакай атыннан төште, җансакчылары аның атын алып калдылар, ә атакай йомшак үләнгә аягы тию белән тезләнде дә Тәңресенә дога кылды.* М.Хәбибуллин. *Ярты аршын буе куелыктагы үлән арасында, каен төбендә, айга каршы бер карт адәм шинель өстендә тезләнгән хәлдә утырып тора иде.* Ф.Вәлиев

2) *куч.* Баш ию, түбәнчелек күрсәтү. *Пётр патша галиҗәнапларының алдына барып тезләнеп, сез аңардан тагын биш полк сорап алдыгыз.* В.Имамов. *Мәскәүгә каршы орышыр өчен гаскәр сорап, Казан ханы Сәхип Гәрәй тезләнеп ялварды, әмма бу ялваруларны Сөләйман колагына да элмәде.* Р.Батулла

3) *куч.* Тирән хөрмәт күрсәтү, ихтирам белдерү. *Безгә, бу ике олы шәхесне, милләтебезнең йолдызларын тәрбияләп үстергәннәре өчен, Җаек каласына тезләнеп баш ияргә генә кала.* Р.Вәлиев. *Әдәби гөлбакча күз явын алып утырсын, яңа үсентеләр белән баесын, дисәк, һәрберебез, үз мөмкинлекләребездән чыгып, җиребезгә, телебезгә хезмәт итәргә, аны сакларга, баетырга, аның изгелеген танып, аның алдында

*баш ияргә, тезләнергә бурычлыбыз.* Л.Сәгыйдуллина

4) *күч.* Җиңелү; буйсыну. *Шул сагыш сазлыгына кереп батсаң – бетәсең; синең гарип күңелең, һәр авырлык алдында тезләнеп, аңа баш ияргә генә тора...* Г.Гыйльманов. *87 нче минутта исә «рубин»лы ярымсакчы Роман Еременко ЦСКАны бөтенләй тезләнергә мәҗбүр итте.* Шәһри Казан

5) *күч.* Җимерелү, таркалу, бетү. *Узган чорда авыл хуҗалыгы тармагын үзгәртеп кору, тезләнгән авылны тернәкләндерү, саклап калу юнәлешендә берниндИ дә кардиналь адым ясалмады.* И.Фазлетдинов

**Тезләнә төшү** Бераз тезне бөгү, чүгү. *Тыныч кына елга читенә килде дә, тезләнә төшеп, йөзен, беләкләрен юарга кереште.* Р.Мөхәммәдиев

**Тезләнеп алу** Бер тапкыр тезләнү, кыска вакытка гына тезләнү. --- *яшь шагыйрьләр көшеленә дә остазлары Газинур Морат чишмәсенә килеп бер тезләнеп алу, аның сүз энҗеләрен учында сикертеп карау саваплы фарыздыр, шәт.* М.Галиев

**Тезләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта тезләнгән булу; әлегә, хәзергә, вакытлыча тезләнү. *Мәдинә карчык --- алдында тезләнеп торган Хәлимнең башыннан сыйпый-сыйпый, тәрәзәдән тышка төбәлеп, үзенең бетмәс-төкәнмәс уйларын уйлый башлады.* Г.Гыйльманов

**ТЕЗМӘ** *и.* **1.** 1) *к.* **тезем** (*1–3 мәгъ.*). *Шушы тирәләрдә Уралның урта сырты тәбәнәкләнеп, казах далаларына таба вак-вак таулар, калкулыклар тезмәсе сузылып китә.* З.Зәйнуллин. *Ул бер тезмәне чыккан да, хәле бетепме, чалгы сабына таянып тора.* Ф.Яхин

2) Абзар, лапас кебекләрдә киртәләр, бүрәнәләр, колгалар һ.б.ш.ны тезеп ясаган түшәм, сайгак. *Көндез лапас түбәсендәге тезмәдә кипкән печән күргән идем, бернәрсә дә алмыйча, киттем шул печәнлеккә.* Ф.Хөсни. *Тезмәдән бер култык тукранбаш печәне алып төшеп, кәҗәнең утлыгына салды.* Ә.Гаффар

3) Барысы бергә, тәртип белән аллы-артлы яки барысы да бер якка карап урнашкан кешеләр чылбыры. *Бер минут та үтмәгәндер, нәрсә булганын аңлаганчы, немецларның алдан килгән тезмәсе җиргә ауды.* З.Зәйнуллин

4) *хәрби* Рәт, саф. *– Артка! – дип кычкырды Иванов, аннары тезмә буенча команда бирде. – Отделение, сугышка әзерлән!* Г.Әпсәләмов. *Аның [Тотышның], ничек тә тезмәне өзеп, Ямгырчы би янына үтеп керәсе, ничек тә аның үзе белән генә орышасы килде.* Н.Фәттах

5) Билгеле бер тәртип белән бер-бер артлы узган вакыйгалар эзлеклелеге, күренешләр агышы. *Исмәгыйльнең миен нәрсәдер яндырып үтте, һәм аның аңы яңарып, күз алдына бер-бер артлы вакыйгалар тезмәсе килде.* Ф.Яхин. *Бихисап күп вакыт гомер, маҗаралар, таныш түгел йөзләр аның хәтер тезмәсендә әле алга таба, әле артка таба йөгерешә башладылар...* Г.Гыйльманов

6) Исемлек. *Нәшер ителгән басмалар тезмәсеннән үк күзгә бәрелеп тора бит: төрле яшьтәге, төрле зәвыклы укучыларның ихтыяҗын канәгатьләндерү максаты тормышка ашырыла монда, ифрат киң тәгаенләнешле китаплар чыгарыла.* Д.Морзакаева

7) Бер җеп, чыбык һ.б.ш.га тезелгән нәрсәләр, бәйләм. *Рәхим юл капчыгына бер тезмә кипкән балык салып чыгып китте.* Г.Минский. *Клиндер тезмәсе*

8) *диал.* Чират. *Әллә никадәр сатучылар – тезмәне әйләнеп йөриләр.* М.Фәйзи

9) *шигъ.* Иҗекләре билгеле бер ритмик тәртип хасил итә торган шигырь юлы, такмак, строфа, куплет, мәкаль һ.б.ш. *Табышмаклар гадәттә бер яки берничә җөмләдән һәм сөйләү теленә җайлап әйтелгән такмазалы тезмәләрдән торалар.* Н.Исәнбәт. *Аннан [инверсиядән] чәчмә текстларда мул файдалану, бигрәк тә аерымланган хәлләрне җөмлә ахырына кую сөйләмне тезмәгә якынайта, эчке ритм тудыруда зур роль уйный.* Р.Рахман

10) *әд.* Гомумән шигырь, назым, бәет. *Шушы тезмәләрдә генә дә шагыйрьнең --- чын ир кешегә кирәкле сыйфатларның бер өлеше ачык чагылган.* Ф.Бухарова. *Чынбарлыкка үз бәясен биреп, бүгенге көнне борчыган мәсьәләләрне кыю калкыта ул үзенең тезмәләрендә.* Л.Кәшфи

11) *муз.* Бер темага тупланып, бер-бер артлы уйнала торган әсәрләр тупланмасы. *Мин үз чыгышымда татар халык көйләренә тезмә уйнадым.* Р.Сәләхов. *Әлеге концертта да Ринат үткән гасырның 60–70 нче елларында халык яратып җырлаган көйләрдән тезмә башкарды.* Х.Гайфуллина

12) *лингв.* Ике яки берничә сүзнең үзара синтаксик бәйләнеп, бәйләнеп ясалган берлеге. --- *тәрҗемә барышында, --- бер телдәге сурәтләү чаралары, шигъри детальләр икенче тел өчен гадәти сүз тезмәләре генә булып калуы бар.* Р.Миңнуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берсе артыннан берсе тезелеп киткән. *Моннан Актай авылы, бераз арырак сузылып киткән тезмә калкулыклар топографик картага төшерелгәндәй ачык күренә иде.* А.Вергазов. *Елганың уң ягындагы тезмә тауларның түбәләре баеп бара торган кояшның соңгы нурларына балкыган.* С.Сабиров

2) Ритмлы итеп, шигырь белән бирелгән, тезмәле. *«Поэма» дип сюжетлы, озын, нинди дә булса җитди проблемага багышланган тезмә әсәргә әйтәләр.* А.Яхин. *Андагы тезмә юлларда аяныч, моңлану, үткәннәр белән бәхилләшү ярылып ята иде.* К.Миңлебаев

3) Сүзтезмәләрнең лексикалашуы алымы белән ясалган. *Билгеле булганча, үзара иярт үле бәйләнештәге ике сүз ул – сүзтезмә, синтаксик берәмлек булып санала, ә кушма һәм тезмә сүзләр алар – лексик берәмлекләр.* Ф.Хисамова

**ТЕЗМӘЛӘНҮ** *ф.* Тезмә барлыкка килү. *Җыентыкка кертелгән 13 оригиналь шигырьнең барысы да бүгенге социалистик төзелешне читтән карап торучының күзе аркылы тезмәләнгәннәр.* Х.Туфан. *Шигырь дә төзек булалмый, Шарт түгел тезмәләнү!* Ф.Яхин

**ТЕЗМӘЛӘҮ** *ф.* Тезмә ясау, тезмә барлыкка китерү. *Бу урында, бәлки, әйтерләр: «Мәкальләрне барын да диярлек болай тезмәләп, бүлгәләп күрсәтү аларны һәртөрле әзер формалы схемаларга көчләп тартып кертү була,*

*асылда, күп кенә мәкальләрдә андый ритм, рифма, үлчәм кебек нәрсәләр бөтенләй юк».* Н.Исәнбәт

**ТЕЗМӘЛЕ** *с.* Тезмәләрдән (*9 мәгъ.*), ритмик юллардан торган, шигъри. *Бу тезмәле романның авторы үзен Котб дип атый һәм әсәрне Низами әсәренә нигезләнеп язылганлыгын әйтә.* И.Мөхәммәтҗанов

**ТЕЗМӘЛЕЛЕК** *и.* Тезмәле булу. *Тезмәлелек мәсьәләсендә Мингалим шигъриятенә тел-теш тидерерлек түгел. Әсәрләренең катлы-катлы шигъри бөтенлеккә корылуы сокландыра, гаҗәеп, бик гаҗәеп...* Ф.Яхин

**ТЕЗМӘ́-ТЕЗМӘ** *с.* Күп тезмәләрдән торган, тезмәләре тезелеп киткән. *Җирдә яшибез дисәгез, җир киң, күккә күтәрелергә дисәгез, тауларыгыз тезмә-тезмә.* Ә.Баян

**ТЕЗҮ** I *ф.* 1) Билгеле бер сызык, линия буенча бер-берсенә янәшә яки бер-бер артлы бер тезем итеп урнаштыру. *Иртән, ишегалдына чыгарып тезеп, физик күнегүләр ясаталар иде.* А.Тимергалин. *Зәңгәр мотоцикл бишегенә утырган кәләпүшле бер карт, шул күпер башында атларны бер сызыкка тезеп, соңгы хәер-фатихасын бирде.* В.Имамов

2) Билгеле бер тәртип белән яссылык өстенә урнаштыру. *Бер калай дучмак тезеп, аларны канат белән майлап, мичкә тыгарга йөри.* А.Тимергалин. *Ул әле, йокларга ятмыйча, безне көтә, хәзинәдә барын өстәлгә тезеп, сыйхөрмәт әзерләгән.* Ф.Хуҗин

3) Бер төрле әйберләрне бер сызык буйлап, берәр фигура ясап яки үзәге аша нәрсә дә булса үткәреп урнаштыру. *Кунак бәрәңгене шашлык кебек итеп турамы-турамы белән тимерчыбыкка тезеп, учакта кыздырып ашарга ярата иде.* Ф.Яруллин. *Аның янында --- энҗе ташлар тезеп, ак төлке тиресеннән тегелгән затлы бүрек кигән тагын бер кеше бар.* В.Имамов

4) Чыбык, юкә, камыш кебек нәрсәләрне рәттән тыгыз итеп кую. *Агач ботакларын тезеп, биек читән тоткан, аның баш-башын тоташтырып, стенасын үзле балчык белән сылап чыккан.* Г.Гыйльманов

5) Нәрсә дә булса кору, төзү, оештыру, ясау. *Табын тезә, чәчәкләр өләшә, режиссёрга, артистларга рәхмәтләр яудыра.* К.Тимбикова. *Берничә ир әзер чокырларга тимер баганалар утырта, аларга җепсәләр сузып, тактадан коймa тезә.* Ф.Хуҗин

6) *күч.* Эзлекле итеп бәйнә-бәйнә сөйләү, әйтү, язу. *– Склад менә бу турыда, – дип, Сабит һәммәсен бәйнәбәйнә тезеп аңлатса да, Кадрия, --- икенче катка менеп, бөтен ихатага югарыдан торып күз ташларга булды.* В.Имамов

7) *күч.* Сүгү, ачулану, әйтмәгәнне калдырмау. *Тезә генә тегe: комиссия белән булган вакыйганы да ачып салды, графиктан тыш отпускага җибәрүне дә калдырмады.* Д.Бүләков

8) *күч.* Берсенә берсен ялгап, такмак, җыр җырлау, көй уйнау яки шигырь әйтү. *Ярсып-ярсып, дәртләнепдәртләнеп тезә көен, өздерә, күңелне тәмам әсир итә.* И.Гыйләҗев. *Тезә улым матур көйләрне.* Г.Гайнетдинова

9) *күч.* Еш, күп тапкыр, кабат-кабат бер үк сүз язу, билге кую һ.б.ш. *Ул математикадан халык җырчысы Миңгол Галиевкә гел бишле генә тезгән.* Р.Газиз

**Тезә бару** *к.* **тезеп бару**. *Әнә ташчы егетләр, кельмаларын ялт-йолт уйнатып, ак силикат кирпечләрне берәмтекләп тезә баралар.* Н.Хәсәнов. *Уйланып-сайланып тормый, кайсы эләгә, шуны такыясына тезә бара.* Р.Габделхакова

**Тезә башлау** Тезәргә тотыну. *Фатыйма аның чалмасын салганын да көтмичә тезә башлады.* Әкият. *Разия пылаудан бушаган тәлинкәләрне җыеп алды да өстәлгә чәй тәмнәре, чәчәкле чынаяклар тезә башлады.* А.Әхмәтгалиева

**Тезә бирү** Бернигә карамый тезүен дәвам итү. *Ильяска шул гына кирәк, такмаклары беткеле түгел, үзенең дә, түгәрәкнең дә күңеле булганчы тезә бирсен әле.* Ә.Баян. *Сергеев, Кудрявцевка якын ук килеп, ялагай тавыш белән тезә бирде.* В.Имамов

**Тезә төшү** Тагы да бераз тезү

**Тезеп алу** Тиз генә тезү; бераз гына тезү

**Тезеп бару** Һәрберсен, булган берсен тезү. *Һәр укыганы саен, ялгыша күрмим дип, өстәл өстенә шырпылар тезеп бара.* Ф.Җамалетдинова

**Тезеп бетерү** Барысын да тезү, беткәнче тезү. *Ашамлыкларны тезеп бетергәч, хатын кеше буш савытларны җыеп чыгып китә.* Э.Яһудин. *Әбдүш китапларны тезеп бетерә дә, кесәсеннән түбәтәй чыгарып, башына киеп куя.* Н.Кәримова

**Тезеп бирү** Тезергә ярдәм итү; башыннан ахырына җентекләп, бөтен нечкәлекләре белән тезү. *Рәдиф барысын да бәйнә-бәйнә тезеп биргән.* В.Нуруллин

**Тезеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта тезү. *Хөршидәттәй савыт-сабаларны юып, киштәләргә тезеп йөргәндә, буфет эчендәге җиз калайның тәмам каралып китүен күреп алды.* А.Тимергалин

**Тезеп калу** Тезәргә өлгерү. *Җәмилә, ире йодрыгын төйнәп өстенә ташланганчы, тезеп калырга ашыкты.* Н.Гыйматдинова

**Тезеп карау** Тезергә омтылу. *Бүген күргән-ишеткәннәренең барысын да барлап, тәртипкә китереп, бер җепкә тезеп карарга тырышты.* Ф.Баттал

**Тезеп китү** Берсе артыннан берсен тезү. *– Такси тотарбыз, ун минуттан миндә булырбыз, паспортыңны да котлыйсы бар! – дип тезеп киттем мин, Азатка авыз ачарга да бирмичә.* А.Тимергалин. *Артык сорауларга урын калдырмыйча, Бородулин үзе тезеп китте.* В.Имамов

**Тезеп кую** Алдан тезү; тезгән хәлгә китереп калдыру. *Барысы да – коллар да, җарияләр дә хан аяк астындагы җирне үптеләр, табакларны башларыннан алып, идәнгә тезеп куйдылар.* Әкият. *Стена буена тезеп куелган урындыкларның берсенә утырды.* Р.Рахман

**Тезеп тору** Бертуктаусыз тезү; әле, хәзерге вакытта тезү. *Конвейерга салган кебек, йорт арты йорт --- бертуктаусыз төзеп тезеп тора.* Л.Мөгътәсимова

**Тезеп чыгу** Барысын да бер-бер артлы тезү; башыннан ахырына кадәр тезү. *Ул [Гали] шахматны тактага*

*тезеп чыга*. Әкият. *Дәфтәр битенә без юньсез дип санаган кешеләрнең исемләген тезеп чыктык*. И.Диндаров

**Тезеп яту** *сөйл. к.* **тезеп тору**. *Хәсән Галигә җибәрү өчен, мәкальләрне тезеп ятам*. Ә.Дусайлы

**ТЕЗҮ** II *и. лингв.* Сүзләрнең, берберсенә иярмичә, бер-бер артлы килү тәртибе белән билгеләнә торган бәйләнеше. *Теркәгечләр ияртү яки тезү бәйләнешләрен тәгъбир итә.* Ф.Хисамова

**ТЕЗҮЛЕ** *с. лингв.* Җөмләдә сүзләрнең һәм җөмләләрнең, бер-берсенә иярмичә, бер-бер артлы килү бәйләнешеннән гыйбарәт. *Кушма һәм тезмә сүзләр, мәсәлән, үзара ияртүле бәйләнештә булган сүзләрдән (ташкүмер, тимерьюл), ә парлы сүзләр үзара тезүле бәйләнештәге сүзләрдән барлыкка килә (ата-ана, бала-чага, әйбер-кара).* Ф.Хисамова

**ТЕИЗМ** *и. гр.* 1) Гомумән дөньяны яраткан Аллаһка, илаһларга ышану, дин. *Имансызлар критик масса чиген узгач, җәмгыять катастрофага (Бөек Туфанга) юлыккан, ә инде Нух пәйгамбәр токымын андый җәзадан саклау ниятендә дин (теизм) уйлап чыгарылган һәм илаһи гыйлемне саклау өчен мистерияләр оештырылган.* Р.Сафин

2) Бердәнбер Аллаһны дөньяны яратучы һәм аның белән идарә итүче абсолют бөек зат итеп күзаллый торган дини-фәлсәфи тәгълимат

**ТЕИСТ** *и. рус* Теизм тарафдары

**ТЕК** I *и. малай* Корычагачлар семьялыгыннан, муссон урманнарда үсә торган нык үзагачлы кыйммәтле токымлы агач; *русчасы*: **тик**. *Тагын бездә [Сирандип әйләнә-тирәсендә] бер җанварның да теше үтми, судан да, салкыннан да курыкмый торган тек агачы бар*. Әкият

**ТЕК** II *с.* **1.** Вертикаль һәм туп-туры. *Ашъяулык астына бер тек шырпы куеп калдырыла, башкаручы шул шырпы өстенә шешәне янтайтып куя да, тигезлек саклау ноктасын тапкач, кулын җибәрә*. Р.Гарифуллин

**2.** *рәв. мәгъ*. Вертикаль рәвештә, бастырып, тегеп. *Тек кую*

**ТЕК** III *кис. рус сөйл.* 1) Нәрсәнең дә булса югары сыйфатка лаек булуын раслап әйтелә; «менә ичмасам!», «дисәң дә ярый!» мәгънәсендә. *Әҗмәкәйдә кичә «Чингачгук – Олы Елан»ны күрсәттеләр, ну, киносы тек киносы да инде!* В.Имамов. – *Менә ичмасам бу гармун тек гармун! – дип, башта әйләндерә-әйләндерә карады, телләренә баскалап, тавышын тыңлады.* Г.Галиева

2) Кире сыйфатның һаман (бу очракта да) саклануын белдереп әйтелә. *Ләкин хайван аңгыра тек аңгыра шул, бердәнбер котылу юлы шушында тыныч кына тупланып тору икәнен аңларга теләми, күк күкрәгән саен куркышып, авыл ягына койрык чәнчеп чабу ягын каера*. Н.Әхмәдиев. *Ни көтәсең аннан, дивана тек дивана!* Ә.Баян

3) «Күрәсезме нинди?», «ис китмәле» мәгънәсендә. *Вәт тек мәхәббәт!* Ф.Яруллин

4) Шартны белдергән сүзләрдән соң «очракта, хәлдә, булса» мәгънәсендә. *Тырышып эшли башладың тек, теге рәсемне үз кулым белән ертам да ташлыйм*. А.Алиш

5) Катгыйлык төсмере өсти; «дигәч» мәгънәсендә. *«Булмый тек булмый. Булмаганга элеп булмый», – диде дә, эшем кешесе кебек, кырт борылып китеп барды*. Г.Гыйльманов. *Әрбир белән җумаламагыз да, хөкүмәт ызбасына бармыйм тек бармыйм!* Н.Гыйматдинова

**ТЕК** IV *иярт.* Каты әйбер белән каты өслеккә җиңелчә бәреп торганда яки тимер өслеккә бәреп яңгыр яуганда чыккан көчле булмаган саңгырау тавышны белдерә. *Ник дисәң, бүлек коридоры буйлап, тек тә тек басып, тәккә арт иләп йөрүчеләр артты*. Н.Хәсәнов. *Ә мин аңа игътибар итмичә, гамьсез генә суккалый бирдем: тек, тек, тек-тек-тек; тек, тек, тек-тектек*. Р.Зәйдулла

**ТЕКӘ** *с.* **1.** 1) Җир өсте тигезлегенә, офыкка нисбәтән вертикальгә якын зур почмак ясап торган; *киресе:* **сөзәк**. *Керәшәләр ояларын текә ярга ясый*. Р.Батулла. *Алда ап-ак болытлар бөркәнгән биек таулар, ишелеп төшәр сыман күренгән текә таш кыялар.* Т.Шәрәфиева

2) Юнәлешен, тар почмак ясап, кискен үзгәрткән. *Бу юл тау астына таба бара һәм упкынга берничә метр кала текә борылыш ясый.* Р.Нуруллин. *Ак йолдызлар сибелгән могҗизалы күктә аяк араларына таяк кыстырган убырлар очып йөри, һәм алар, текә пике ясап, берәм-берәм аланлыкка очып төшәләр.* Казан утлары

3) Киң һәм төз. *Ләкин чын күңелдән шатланырга бер нәрсә комачаулык итте: ул да булса, егетнең текә маңгае астыннан сөзеп карап куюы*. М.Маликова

4) *күч.* Кырыс, таләпчән, усал. *Иннокентийны үтмәс пычак белән телгәләгән текә холыклы сержант инде элеккечә гайрәтле түгел иде.* З.Мәхмүди

5) *күч.* Үзен башкалардан күпкә өстен санаган, башкалар белән санлашмый торган; зур мөмкинлекләргә ия булган, шул мөмкинлекләрдән файдаланган, кәттә. *Шунда гына текә түрәнең исенә төшә иске дусты...* Ә.Дусайлы. *Казанның текә байлары артыннан гади халык та ияреп, болындай киң мунчалар салырга керешә*. Э.Фатыйхова

6) *күч.* Нинди дә булса сыйфаты белән үз ишләреннән күпкә өстен, кайсыдыр ягы белән шаккатыргыч булган. *Мөмкин булган саен озын чәчләргә сүз катмыйча калмый үзе, әлбәттә, ләкин кызыл иреннәргә текә машиналы, чибәр, бай егетләр кирәклеге беркемгә дә сер түгел*. Ә.Галиева

**2.** *и. мәгъ.* Текәлек. *Биектә, текәдә, --- йокысыннан уятылган яман капландай, ак шом дерелди, селкенә, шуыша башлар, кар көртләре, өемнәре түбән очучы ак ташкынга әйләнер.* Г.Хөсәенов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Тек, вертикаль рәвештә, туп-туры өскә каратып. *Өйгә кергәч тә безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә утырган бер бабай булды*. Ә.Еники

2) Кинәт һәм кискен хәрәкәт ясап. *Һәм, текә генә иттереп, китәсе юлыннан йорт эченә борылды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

3) *күч.* Кырыс, усал итеп, шелтә белдереп. – *Нигә килеп керүгә үк белдермәдегез монда икәнлегегезне? – дип, Солтанга текә генә карап куйды*. Ф.Яхин

4) *күч.* Кискен, көтелмәгән рәвештә. *Сәет урман сакчыларын сыйлап, агач кисүчеләрне майлап йөргәндә, аның дөньяга карашын, киләчәген текә үзгәртеп куйган хәлләр булган икән шул.* Т.Галиуллин. *Тик менә азык-төлекнең бик текә кыйммәтләнүе һәм газның хакы күпкә арту белән генә һич тә килешеп булмый.* Р.Миңнуллина

5) *күч.* Тәкәббер, эре, үтә булдыклы, бөтенесеннән дә өстен булырга тырышып. *Вәт бит, ә! Үзенчә текә булып күренәсе килгәндер инде.* Д.Алмазова

◊ **Текә баш(лы)** Үзен тәкәббер, бик эре, башкалардан өстен тоткан кеше турында. *Текә башлы буш кешеләрне автор богдай башаклары белән чагыштыра, башлары иелгән тук башакларны мактый.* А.Вәлиуллина. **Текә борылыш** Көтелмәгән үзгәрешләр. *Кеше тормышында текә борылыш мизгелләре әлләни күп булмый.* Ә.Дусайлы. **Текә борын(лы)** *к.* **текә баш(лы)**. *Әле яңа гына дию пәриедәй дөньяларны дер селкеткән текә борын Чәлдери эреде дә китте.* Ф.Яхин. **Текә күтәрелеш** Тиз арада бик нык үсеш, көтелмәгәнчә алга китеш. *Терлекчелек текә күтәрелеш ала.* Г.Мөхәммәтшин. **Текә муен(лы)** *к.* **текә баш(лы)**. *Әйе, бу тәкәббер чибәрнең текә муенын бөгәсе, чөелгән башын идерәсе килде аның.* М.Маликова

**ТЕКӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Текәлеге арту, текәгә әйләнү. *Чагыл тавының Минзәлә инеше ягыннан текәләнеп күтәрелүе һәм югарыдан тәгәрәп төшкән ташның аска таба омтылып очуы исә котларны ала.* Ф.Яхин. *Тау шулкадәр текәләнде, хәзер иелеп, ташларга таянатаяна атларга, кайбер урыннарда үрмәләргә туры килде.* Көмеш кыңгырау

2) *күч.* Кырыслану, холык-фигылендә корылык барлыкка килү; тәкәбберләнү, эреләнү. *Чит илдә пикаплар фермерларга тирес, силос ташу өчен хезмәт итсә, бездә аны кыйммәт бәягә алып, «текәләнеп» йөриләр.* Шәһри Казан

**Текәләнә бару** Акрынлап, аз-азлап текәлеге арту. *Кояш текәләнә барган саен, агач, куак кәүсәләрендә хәрәкәт көчәя, яшәү каны кайнарлана.* Р.Газиз. *Тауның итәге сөзәк, үргә таба текәләнә бара, текәләнә бара, ә түбәсе футбол мәйданы кадәре тип-тигез мәйдан хасил итеп очланган.* Ә.Әминов

**Текәләнә башлау** Текәләнергә тотыну

**Текәләнә төшү** Тагын да текәләнү

**Текәләнеп алу** Берникадәр текәләнү

**Текәләнеп бетү** Тәмам, бик нык текәләнү

**Текәләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта текәлек күрсәтү

**Текәләнеп китү** Кинәт текәләнү, текәрәк булып күренү. *Сазлыкка килеп төртелгән җирендә тау тагын да биекләнә, тагын да текәләнеп китә.* Х.Садрый

**Текәләнеп тору** Әле, хәзер, күз алдында текә булып күренү

**ТЕКӘЛӘҮ** *ф. диал. к.* **текәлү**. *Йөзенә, кыланышына текәләп караганнан соң, думбрасын кулына алып, бу әйтелгән илченең үткәнен һәм киләчәген әйтеп, кемлеген ача башлый.* Н.Исәнбәт. *Шунда Гыйззелбанат үзен йотлыгып тыңлаган Маһирәгә текәләп карап алды да сүзен дәвам итте.* Г.Галиева

**Текәләп тору** Әле, хәзерге вакытта текәләү. *Ирләр аңа түгел, кар өстендә аунаган мәетләргә текәләп тора иде.* В.Имамов

**ТЕКӘЛДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **текәлү**. *Аннары Фәрхизә, күзләрен кысыбрак, йөзенә сихәтле елмаю җәеп, Әхмәдиярның карашын үзенә текәлдерә.* М.Хуҗин

**ТЕКӘЛЕК** *и.* 1) Текә булу. *Кайчагында бу үр артында биеклеге һәм текәлеге белән кызыктыргыч тау да чагылып киткәндәй була.* Ә.Гаффар

2) Текә урын, текә битләү. *Инде текәлек буйлап тау өстеннән бара идек.* Н.Исәнбәт

3) Текә булу дәрәҗәсе, авышлык. *Мин хәзер баскычның текәлеген дә, кулдагы баланың авырлыгын да тоймадым.* Н.Фәттах

4) *күч.* Кырыслык, корылык; тәкәбберлек, эрелек. *Күрәсең, текәлек һәм тәкәбберлек заманнан гына түгел, тәрбиядән дә килә торган сыйфатлардыр.* Ф.Сөнгатуллина. *Телевизор экраннарыннан, кинофильмнардан, Интернет челтәреннән агылган бу тискәре күренешләрне һәм сыйфатларны сеңдереп үскән яшьләр аларны инде яшәү рәвеше, текәлек дип кабул итә башлады.* Ф.Зариф

**ТЕКӘЛЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **текәлү**. *Егет тә аягүрә басты, алар, берберсенә текәлешеп, беренче кат очрашкан ят кешеләр кебек сынашып тордылар.* А.Гыйләҗев

**ТЕКӘЛҮ** *ф.* 1) Берәр ноктага, әйбергә күзләрен төбәп, игътибар белән карап тору; күз дә алмыйча дикъкать белән күзәтү. *Ул барактан чыгып китә, кашларын җыерып, тимерчыбык киртәләргә текәлә.* Г.Әпсәләмов. *Менә ул, --- кулын селтәп, бүкәнгә барып утырды, тонык картлык пәрдәсе өрткән күзләре миңа текәлде…* И.Гыйләҗев

2) *диал.* Килеп терәлү, килеп төртелү. *Эшнең уңышлы тәмамлануы акчага текәлгән*

**Текәлеп алу** Аз гына, кыска вакытка текәлү. *Сафуанны да табиб дип уйлаган рәссам, үзем китсәм, мондагы бәхетемнән мәхрүм калмаммы дигәндәй, тагын бер мәртәбә ишеккә текәлеп алды да тикшерүчегә иярде.* Ф.Баттал

**Текәлеп бетү** Тәмам, тулысынча текәлү. *Тегенең карашы кырыс йөземә текәлеп беткәч кенә, кырт кына сорап куйдым: – Теге фәлән номерлы кара мотоциклны кая куйдыгыз?* Ф.Баттал

**Текәлеп кую** Бер тапкыр текәлү. *--- аулаграк почмакка баскач, йөземә тагын текәлеп куйды.* Ф.Баттал

**Текәлеп тору** Билгеле вакыт дәвамында текәлү; әле, хәзерге вакытта текәлгән булу. *Лимон Бананович күршесенең елтыр пеләшенә, көзгегә карап торгандай, озак кына текәлеп торды да башын артка ташлап шаркылдады.* Ф.Баттал. *--- ә бу кандаладай кадалырдай булып текәлеп тора.* Ф.Баттал

**ТЕКӘНӘК** *и.* Чәнечкеле, тикәнле үсемлекләрнең уртак атамасы. *Курай эченә кысылып, әремле әрнеп җил җылый, саз кылыннан йөгерек кылганнар, текәнәкләр телендәге дала өне сыктап тарала.* Н.Нәҗми

**ТЕКӘНӘКЛЕ** *с.* Чәнечкеле, тикәнле, текәнәкләре күп булган. *Текәнәкле үсемлекләр*

**ТЕКӘНӘКЛЕК** *и.* Текәнәкле үсемлекләр күп үскән урын. *Текәнәклеккә килеп керү*

**ТЕКӘҮ** *ф.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса күзне төбәү, кая булса да карашны юнәлтү. *Бармак янады танышым, мәгънәле дә, сагайткыч та карашын йөземә текәп.* Ф.Баттал. *Врач күзләрен аска текәде, ирennәрен кысып кына пышылдавын дәвам иттерде.* К.Тимбикова

**Текәп тору** Әле, хәзерге вакытта текәгән булу. *Гайнан абыйсының, мисал чишкәндәге төсле, башын кырын салып, күзләрен бер ноктага текәп торуыннан Рәфиснең көләсе килеп китте.* Н.Әхмәдиев. *Ә ул аз гына гаҗәпсенеп, сөйкемле кара күзләрен миңа текәп торды да кинәт ачылып китеп көлеп җибәрде.* В.Нуруллин

**ТЕКӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **текәү**. *Болар икесе – озата йөрүчебез һәм үтә артык кызыксынучыбыз – үзара карашып, күзләрен бер-берсенә текәштеләр.* Ф.Яхин

2) *диал.* Берәр нәрсәнең каршына килеп төртелү. *Диварга килеп текәшү*

3) *диал.* Бер-берсенә якын ук китереп, кысып тоту; терәшү. *Алар, басма өстендә бер-берсенә юл бирмәгән ике кәҗә тәкәсе сыман мөгезләрен текәшеп, тынып калдылар.* А.Хәлим

4) *күч.* Берәр нәрсәгә хәтле килеп җитү, ирешү, барып тоташу. *Яңа җиткәнче ашарга бер подаука он, бер капчык бәрәңге биргәннәр ие, --- шуның белән яңага килеп текәштек.* Г.Бәширов

**Текәшеп кую** Текәшкән хәлгә килү

**Текәшеп тору** Билгеле вакыт дәвамында текәшү. *Күзгә-күз текәшеп торганнан соң кочаклашалар.* Р.Әбделмәнев

**ТЕКЕЛДӘТҮ** *ф.* Берәр нәрсәне бәргәләп, эшләтеп, тек-тек иткән тавыш чыгарып тору. *Сиңа инде «Зингер» машинасында текелдәтеп әйбер генә тегеп утырырга туры килер.* С.Ибраһимова

**Текелдәтә бару** Торган саен көчләрәк текелдәтү

**Текелдәтә башлау** Текелдәтергә тотыну. *Кайткач, тагын компьютер артына утыра, бармаклары хәреф төймәләрен текелдәтә башлый.* Туганайлар

**Текелдәтә бирү** Бернигә карамый текелдәтүен дәвам итү. *Ул башын селкеп кенә куйды, күзен тегүеннән алмады, машинасын текелдәтә бирде.* Г.Якупова

**Текелдәтә төшү** Тагын да ныграк яки бераз дәвам итеп текелдәтү

**Текелдәтеп алу** Кыска вакыт арасында текелдәтү. *Машинасын текелдәтеп ала да ил халкын көлмәкле итә дә куя.* Ф.Яхин

**Текелдәтеп йөрү** Төрле урыннарда бертуктаусыз текелдәтү. *Мондый башмакларны киеп, урам ташларын тектек итеп текелдәтеп йөрүе ни тора.* Д.Аппакова

**Текелдәтеп кую** Бер тапкыр текелдәгән тавыш чыгару

**Текелдәтеп тору** Бертуктаусыз текелдәтү

**ТЕКЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Тек-тек итү, тектек иткән тавыш чыгу. *Көн саен станогым минутлап кына түгел, сәгатьләп бушка тора яки бушка текелди.* Г.Кутуй. *Стенага эленгән сәгать теле генә үз җаена текелди.* Н.Каштанов

2) Мылтык, автомат, пулемёттан өзлексез атып тору. *Сул яктагы автоматчы текелдәргә кереште, тик Золотарёв нигә суза соң?* Р.Низамиев

3) *күч.* Бертуктаусыз нидер сөйләнү, бытылдау. *Илгиз өзлексез текелдәп, әледән-әле әнисе белән әтисенең куллары на асылынып, я сикергәләп барганнан соң, әтисенә һөнәрен күрсәтергә теләде.* А.Расих

**Текелдәп алу** Бераз, кыска вакыт дәвамында текелдәү

**Текелдәп йөрү** Һаман, бертуктаусыз текелдәү

**Текелдәп кую** Бер тапкыр текелдәгән тавыш чыгару

**Текелдәп тору** Берөзлексез текелдәү. *Рәхилә, тиз генә озатып куйыйм дисә дә, бик озак кибет ишеген бикли алмый азапланды, бикләгәч, әле генә текелдәп торган булса да, сөйләшергә сүз тапмады.* Р.Рахман

**Текелди бару** Тагын да ныграк текелдәү. *Казанга якынлашкан саен, поездның тәгәрмәчләре ныграк һәм ачыграк текелди бара иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Текелди башлау** Текелдәргә тотыну. *Кабынды бит, бер көйгә генә текелди башлады.* В.Нуриев

**Текелди бирү** Бернигә карамый текелдәвен дәвам итү. *Югыйсә инештә сулар ага, фирүзә күктә болытлар сәяхәт итә, диварга элеп куелган сәгать бер хыянәтсез текелди бирә.* Н.Әхмәдиев

**ТЕКЕР** *иярт.* Акрын гына атлап барганда яки нинди дә булса механизм бер ритмга эшләп торганда чыккан бик үк көчле булмаган тигез тавышны белдерә. *– Кемне сагалап посты икән бу явыз? – дип борчылып, як-якка каранса, текер-текер атлап килеп яткан таныш Керпене күрде.* Әкият

**ТЕКЕРДӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **текердәү**

2) Текерт-текерт иткән тавыш чыгарып нинди дә булса каты әйбер кимерү; кетердәтү. *Нәрсә текердәтәсең син, апаем?* Н.Гыйматдинова

**ТЕКЕРДӘ́Ү** *ф.* Текерт-текерт иткән тавыш чыгарып тору. *Кызганыч, шунда [трамвай-ресторанда] текердәп кенә шашлык кимереп барасы килгән иде.* Татарстан яшьләре. *Ерак Көнчыгышка таба текердәгән поездда, Байкал күле буенда дөньяга китергәндә, Фәридә Нуриева улының дөньякүләм танылган шәхес, диңгез утраулары сатып алырлык иң бай биюче булачагын хыяллана да алмагандыр, мөгаен.* Кызыл таң

**Текердәп алу** Аз гына, кыска вакыт текердәү

**Текердәп кую** Кинәт кенә текердәгән тавыш чыгару

**Текердәп тору** Бертуктаусыз текердәү

**Текерди бару** Торган саен ныграк текердәү

**Текерди башлау** Текердәргә керешү. *Тагы берничә сүз ишетелде дә, [тегү] машина[сы] текерди башлады.* Г.Ибраһимов

**Текерди төшү** Тагы да ныграк текердәү

**ТЕКЕРТ** *иярт.* 1) *к.* **текер**. *Төнлә текерт-текерт [килеп кергән сарыкларның] тояк тавышына уяндым, ди.* Н.Гыйматдинова

2) Бер тапкыр текердәгән авазны белдерә. *Сәгать текерт итте дә туктап калды*

**ТЕКЕ́Р-ТЕКЕР ИТҮ** *ф. к.* **текердәү**

**ТЕКЕ́Р-ТЕКЕР КИЛҮ** *ф. к.* **текердәү**

**ТЕКМӘ** *и.* **1.** Колгаларны яки баганаларны тек бастырып тезеп ясаган киртә. – *Су азрак икән шул быел, – диде Утташ кам, текмә янына килеп.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Колгаларны тек бастырып тезеп ясаган. *Сәндерәдән озын корык суырып алды да, бер кулына камчы, икенчесенә шул чыбыкны тотып, тайларны текмә читән буена өерләп китерә һәм кысрыклый башлады.* Х.Камалов

**ТЕКМӘЛӘ́Ү** *ф.* Текмә белән әйләндереп алу, текмә белән киртәләү. *Бакча текмәләү*

**ТЕКМӘ́-ТЕК** *рәв.* **1.** Төп-төгәл; тулысынча. *Динилек белән дөньявилыкны текмә-тек капма-каршы куярга ярамый.* Р.Рахман

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* «Тулысынча бердәй, тулысынча туры килә» мәгънәсендә. *Разил Вәлиев мәдхиясен Рөстәм Яхинның «Туган ягым» җыры өчен язган көенә шыңшып карыйм: текмә-тек.* Р.Зарипов

**ТЕКМЕКЛӘ́Ү** *ф. диал.* Җентекләп, җиренә җиткереп эшләү. – *Акчасын кызганмый, көчен кызганмый, нинди мәктәп күрсә, шуны яптырырга тырышып йөридер иде, – дип бәян иткәч, Әхмәт теге татар сурәтенә текмекләп карады.* Ф.Әмирхан. *Анда җирле сөйләм сүзләре дә (табалыйсыгыз, кана, берди, чытлыклану, текмекләп) шактый очрый.* Г.Тукай

**ТЕКСТ** *и. лат.* 1) Кешенең берәр матди җирлектә теркәлгән фикере

2) Берәр гыйбарәне, әдәби әсәрне, документны һ.б.ш.ны тәшкил иткән, билгеле эзлеклелектә һәм бәйлелектә килгән сүзләр һәм җөмләләр җыелмасы. *Фәнни өлкәгә ныграк керү исә, үз чиратында, каләм иясенең нәфис текст төзү осталыгын арттыра.* И.Нуруллин. *Текст астында хакимнең урынбасары, прокурор, милиция башлыгы, олигарх, баш табиб һәм башкаларның имзалары тезелеп киткән иде.* Ф.Хуҗин

3) Нинди дә булса әсәрдән китерелгән өзек. *Һәм бу очракта, хәер – элеграк тә, язучы [Г.Гыйльманов] озын-озын аятьләр, дога текстлары китерә.* Ф.Урманче. *Без ана телебезне онытмасын өчен, әтиебез --- җәйге каникулда көн саен ярты сәгать китаптан нинди дә булса текст күчереп язарга бирә иде.* Г.Шәйхи

4) Әдәби әсәрнең, документның һ.б.ш.ларның искәрмә, астөшермә, аңлатма кебекләрне исәпкә алмаган төп өлеше

5) Музыкаль әсәрнең сүзләре. *Хәлбуки «Кәккүк»нең көе Солтан Габәши тарафыннан Г.Рәхим текстына язылган, һәм беренче тапкыр бу җыр текст авторының үз өендә җырланган.* М.Мәһдиев. *Әзер көйгә текст язылырга тиеш түгел, дип исәпләмим мин.* И.Юзеев

**ТЕКСТИЛЬ** *җый. и. лат.* **1.** Һәртөрле тукымалар. *Сәнәгать җитештерүендәге үсешкә тире һәм киемсалым, текстиль, резин һәм пластмас әйберләр, электр җиһазлары, электрон һәм оптик җиһазлар эшләп чыгару да зур йогынты ясаган.* Р.Шакир

**2.** *с. мәгъ.* Тукымадан торган, тукымадан гыйбарәт. *Тышкы сәүдә әйләнешенә килгәндә, Татарстан – Беларусьның сәүдә партнёры: 2006 елда Татарстанга Беларусьтан килгән импортның төп өлешен тракторлар, механик җиһазлар, текстиль материаллар тәшкил итә.* Ватаным Татарстан

**ТЕКСТИЛЬЧЕ** *и.* Текстиль сәнәгатендә эшләүче кеше. *Ораторның тузган чәче трибуна өстендә җил белән тузгыла башлауга, татарлардан текстильче Галимов каты кул чабып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *[Төркиянең] Премьер урынбасары Назым Әкрән, соңгы биш елда 730 миллион доллар акча чит илләргә китте, текстильчеләр чит илләргә кредит салдылар, дип белдерде.* Шәһри Казан

**ТЕКСТИЛЬЧЕЛЕК** *и.* Текстиль эшләп чыгару эше, һөнәре, сәнәгате. *Текстильчелек алга киткән*

**ТЕКСТЛЫ** *с.* Эченә нindидер текстны алган; тексты бар. – *Реклама булгач, мәгез, реклама итеп ясап кертегез! – дип, егеткә текстлы кәгазен һәм фотоны кире бирде.* Ф.Яхин

**ТЕКСТО́ЛОГ** *и. рус* Текстология белгече. *Болгар, Алтын Урда ханлыгы чорларына караган зират-каберлекләрнең каберташ язмалары --- тарихчылар, текстологлар тарафыннан өйрәнелгән.* Н.Гариф

**ТЕКСТОЛО́ГИК** *с.* Текстологиягә караган, текстологиягә бәйләнешле. *Г.Сөнгатинең кыска гына иҗат дәверендә шактый күпсанлы – 100 гә якын исемдәге шигырь авторы икәне мәгълүм булды. Боларның барысы буенча (поэма, баллада һәм хикәясен дә кертеп) текстологик тикшеренү уздырылып, алар бүгенге укучы кулына бирерлек рәвешкә китерелделәр.* З.Рәмиев

**ТЕКСТОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Филологиянең әдәби һәм башка язма әсәрләрнең дөрес текстын аныклау белән шөгыльләнә торган тармагы. *Конференциядә Гаяз Исхакый иҗаты төрле яктан яктыртылды, аның әсәрләрен басу буенча текстология мәсьәләләре күтәрелде.* М.Вафин. *Текстология фәне татар әдәбият белемендә гаять зур урын алып тора.* Ә.Закирҗанов

**ТЕКСТУАЛЬ** *с. рус* Текстка караган, текстка бәйле. *Коман табышмагы һәм татар табышмагы арасында текстуаль якынлык шактый зур.* Х.Мәхмүтов. *Тәңречелек тәгълиматының текстуаль варианты булмау сәбәпле, камнарда аның мистик ягы гына сакланып, эзотерик фәлсәфәсе җуелган.* Р.Сафин

**ТЕ́К-ТЕК** *иярт.* 1) Ритмлы кабатланып торган «тек» тавышын белдерә

2) Сәгать йөргән тавышны белдерә. *Тик диварга эленгән ике герле сәгать кенә вакыт саный: – Тек-тек!* З.Зәйнуллин. *Нидер сөйли тек-тек иске сәгать...* Ф.Дәүләтгәрәева

3) *сир.* Мылтык, автомат, пулемёттан өзлексез атып торган тавышны белдерә. – *Огонь! – лётчик шулай диюгә, ромблы кеше гашеткаларны кысты: тек-тек, тек-тек.* Г.Гобәй

**ТЕ́К-ТЕК ИТҮ** *ф. к.* **текелдәү**. *Тыңлап карарга кирәк: шартлаткыч булса, тек-тек итеп сәгате эшләргә тиеш аның.* З.Хәким. *Тавышның тек-тек итеп аска табан тәгәрәп китүен тоеп торудан рәхәтлек сизеп, ниһаять, җиңел сулап куйды.* Ф.Җамалетдинова

**ТЕ́К-ТЕК КИЛҮ** *ф. к.* **текелдәү**. *Стена сәгате авыр герен идәнгә таба өстерәп тек-тек килә, тын өйдә аның*

*тавышы «юк-юк» дигән кебек булып ишетелә.* М.Мәһдиев. *Солдат, аныңча, сәгать угы сыман, гел тек-тек килеп хәрәкәтләнеп торырга тиеш.* С.Поварисов

**ТЕКТЕРТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тектерү**. *Ул кибетче малайларга, читекче, кәвешчеләргә ак яка киертте, искедән киеп килгән казакиларын искечегә саттырып, һәйбәт бумажный материядән «пинжәк» тектертте ---.* Гали Рәхим

**ТЕКТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тегү** I

2) Тегүчегә тегәргә бирү, тегүчедән кием-салым эшләтү. *Сугыштан кайткач, әнә үзенә өр-яңа тун, өр-яңа толып тектерде.* В.Нуруллин. *Багдад ягыннан килеп, Болгарда төпләнеп калган Габид атлы тегүчегә ул моннан өч ай чамасы элек туй өчен үзенә кара төлкедән кышкы тун, кызыл атластан җәйге тун тектерергә биргән иде.* Н.Фәттах

**Тектерә башлау** Тектерергә керешү. *Хатын-кызлар, кәкре аякларын каплар өчен, озын күлмәк тектерә башладылар, ягъни озын күлмәк кигән хатын-кызны күрсәң, бел: аның аяклары бик үк туры түгел, дигән.* Р.Батулла

**Тектереп алу** Тиз генә тектерү; тектереп әзер итү. *Ул елларда бик модалы саналган баш киеме «испанка»ны мин дә әниемнән тектереп алдым, аны бик горурланып киеп йөрдем.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тектереп йөрү** Әле, хәзер тектерү белән мәшгуль булу. *Хәзерге вакытта Аязга костюм тектереп йөрибез.* Татарстан яшьләре

**Тектереп кую** Алдан тектереп әзер итү. *Аннан соң, ул кайтканчы, яңа күлмәк тектереп куярмын дигән идем.* Р.Сальмушев

**Тектереп тору** Һәрвакыт, еш тектерү

**ТЕКТО́НИК** *с.* Тектоникага (*1 мәгъ.*) караган. *АЭС төзелә торган җир астында тектоник үзгәрешләр, көчле хәрәкәт бара.* Р.Батулла. *Вакыт-вакыт Җир-Ана (инь) белән Күк-Ата (янь) гайрәтле кушылуыннан тектоник тетрәнүләр хасил була.* М.Галиев

**ТЕКТО́НИКА** *и. гр. махс.* 1) Җир кабыгының төзелеше, хәрәкәтләре, деформациясе һәм шулар нәтиҗәсендә булган геологик үзгәрешләр. *Нефть катламының тирәнлеге 180 м, катлам горизонталь, аның гомуми калынлыгы 70 м, нефтькә бай булган өлеше 26 м. Катламга хас үзенчәлек – ярыклы тектоника.* Фән һәм тел

2) Геологиянең Җир кабыгы төзелешен, хәрәкәтләрен, деформациясен өйрәнә торган бер тармагы

**ТЕЛ** *и.* 1) Умырткалыларда тәм тою, азык чәйнәү, күшәү, кешеләргә тагын сөйләү өчен дә ярдәм итә торган авыз куышлыгындагы хәрәкәтчән әгъза. *Аның телен канатканчы тешләттерделәр һәм менә шул тешләнгән теле белән үзен дә утка атачаклар.* Н.Гыйматдинова. *Мәче хуҗаны күргәч, кызыл телен чыгарып, авыз кырыйларын ялмап-ялмап алды.* Н.Хәсәнов

2) Нинди дә булса терлекнең ашамлык итеп әзерләнгән шул әгъзасы. *Менә сыер теленнән авыз ит.* Т.Гыйзэәт. *[Суыткычларның] Икесе дә затлы балык, ысланган ит, тел, тавык ите кебек азык-төлек, сулар, исерткечләр белән дыңгычлап тутырылган.* Т.Галиуллин

3) Җәмгыятьтә кешеләрнең үзара аңлашу, аралашу чарасы булган, фикерләү, уй-фикер нәтиҗәләрен беркетеп бару өчен хезмәт итә торган һәм, гадәттә, һәр милләттә үзгә, үзенчә булган сүзләр, грамматик чаралар системасы. *Тел белмим, юл белмим, кая китим?* Г.Исхакый. *Тел язмышы өчен борчылып, ялкынлы әсәрләр иҗат иткән шагыйрьнең, тел язмышы өчен борчылып, тау кадәрле проблемалар күтәргән журналистның баласы ана телен оныткач, ни дияргә?* З.Мәхмүди

4) Аерым индивидның шул системадан файдалануга сәләте, сөйләшә алуы. *Бу малайның теле юк, ахры, дип уйламый микән Айсылу апасы...* Р.Мөхәммәдиев

5) Шул системаны өйрәнүдән гыйбарәт фән тармагы; уку йортында өйрәтелә торган уку-укыту предметы. *Беренче имтихан математикадан язма эш иде. Өчле алдым. Телдән – икеле. Мин бернәрсә дә белмим икән.* Т.Миңнуллин

6) Әлеге системаның аерым төркемнәренә, һөнәр ияләренә яки аерым фән, сәнгать төшенчәләрен тәгъбирләүгә караган үзенчәлекле варианты. *Гомумән, сәүдә работнигына бер урында бик озак утыру, врачлар теле белән әйткәндә, противопоказано ул!* Ә.Еники. *Шофёрлар телендә моны «сулга китү» дип әйтәләр түгелме?* В.Нуруллин

7) Аерым бер рухияткә, хиссияткә, кәефкә һ.б.ш. туры килә торган сүзләр, тәгъбирләр яки аңлашу чаралары. *Моңа Илгиз үзенчә, күңелендә күп еллар буе изге хис итеп тәрбияләп йөрткән мәхәббәт теле белән җавап бирде: – Бу хакта аз гына да борчылма. Миндәге мәхәббәт икебез өчен дә җитәрлек, – диде ул.* Г.Гыйльманов. *Дуслык телен берүк сата күрмә, Дошманнан да чөймә йөзеңне.* Р.Мостафин

8) Фикерне, идеяне белдерү рәвешендә файдаланылган алымнар җыелмасы; стиль. *Эш теле, аралашу теле, дипломатия теле, интернациональ тел булырга мөмкин, әмма анаң теле, милләтең теле түгел.* Р.Миңнуллин. *Шигъри тел белән Бәпкә үлән борын төртә, Агачларда бөре бүртә.* Р.Әхмәтов

9) Һәрвакыт, еш әйтелеп, кабатланып торган сүз, һәрвакыт искә алынган фикер. *Халыкның күңелендә дә, телендә дә хәзер шул гына: бәрәкәте белән килгән мондый язны күптән күргәннәре юк иде, үкенечкә генә булмасын.* М.Шабай. *Соңгы сулышымны алган вакытта да, минем телдә әнкәй белән син булырсың.* Р.Ишморат

10) *күч.* Сөйләүче кеше. *Һарун белән Мансур тиз-тиз генә эшләрен бетерделәр дә, усал телләр күзенә эләккәнче, алданрак ашап алырга булдылар.* Ә.Еники

11) *күч.* Сөйләү, тәгъбирләү куәсе, осталыгы, сөйләү рәвеше. *Менә кемдә ул тел!* Р.Миңнуллин. *Карасам, Маһруй түти килә, борыч тел!* Р.Батулла

12) *күч.* Фән һәм сәнгатьтә тәгъбирләү чаралары. *Моңлы кәккүк тавышлары, кошларның сак җырлары, аюның салмак йөреше, усал буре улаулары матур музыка теле аша сурәтләнделәр.* М.Җәлил. *Әмма аны [тапкырлау таблицасын] аңлау өчен, башка телне – математика телен, ким дигәндә арифметика телен белергә кирәк.* Фән һәм тел

13) *күч.* Мәҗүси дога, ырым догасы, арбау. *Магик формулаларның аеруча үзенчәлекле үрнәкләре кешегә нинди-дер куркыныч, афәт янаганда әйтелә, «елан теле» дип аталган арбауны әнә шундый формулалардан дип әйтергә мөмкин.* Ф.Урманче. *Безнең халыкта шундый ырым бар: --- янгынны сүндерү өчен һәм утка пешкән урынны дәвалау өчен, ут телен белергә кирәк.* Х.Гайнетдинов

14) *күч.* Сугышта дошман якның торышын, хәлен сөйләтү өчен махсус кулга төшерелгән әсир. *Менә без, төнлә барып, бер «тел»не каптырдык...* Ә.Еники. *Төнлә «тел» алырга чыккан разведчикларыбыз урман аланында немец разведчикларына килеп төртелә.* З.Мәхмүди

15) *күч.* Берәр нәрсәнең кырыенда чыгып торган киртләч, чук. *Акрын шуса да, аның мамык шәленә җил ябышкан, шәл телләре җилдә тирбәлеп иркәләнәләр иде.* М.Хуҗин

16) *күч.* Формасы белән очлаеп торган чыгынты. *Кинәт йозак теленең шылт итеп төшеп киткәнен сиздем.* Ш.Усманов

17) *күч.* Сәгать маятнигы. *Хөснүриянең, үзе әйтмешли, хан заманнарыннан калган җиз гере, җиз теле булган, бик матур итеп суга торган сәгате ничә ел инде моңаеп эленеп тора иде стенада.* Н.Кәримова

18) *күч.* Капкын келәсенә беркетелгән пластинка. *Төлке капкын теленә куелган ит кисәген ашыкмыйча гына алып капкан.* Г.Галиев

19) *күч.* Кыңгырау, чаң, шөлдер кебек әйбер касәсенең эчке ягына, төбенә эленгән тукмакчык. *Сәйфетдин капчыкны пулемёт өстенә куйганда, аның эчендәге кыңгырау теле чыкылдап куйды.* З.Зәйнуллин. *Хатын-кызлар итәгедәй киң балаклы юка чалбар кигән ирләр чиркәүдәге чаң телләре сыман әрле-бирле йөри, билләрендә – ятаган, баш түбәсендә – фәс.* В.Имамов

20) *күч.* Без, кармак кебек очлы әйберләрнең очындагы эләктереп ала торган кечкенә үткен чыгынтысы. *[Бикмуш бабай] Тимерне коры имән утыныннан төшкән кызу күмергә салып кыздырды. Мең бәла белән бөкте. Суытты да, очын игәп, тел ясады. Шулай итә торгач, кармак сыман бернәрсә барлыкка килде.* Г.Гобәй

21) *күч.* Кубызның, уйнаганда, бармак белән эләктереп ычкындырыла торган сыгылмалы пластинкасы. *Кубыз бар иде, Гани телен сындырган.* М.Фәйзи. *Сәфәргали кесәсеннән җиз телле кубыз алып, чирттереп уйнап җибәрде.* Ф.Хөсни

22) *күч.* Гармун һәм башка уен коралының клавишы; резонатор. *Кадер авылына кунакка барып, сигез телле бозык гармуннарын уйнап, бөтен авыл халкын шаккатырып кайткан.* Р.Батулла

23) *күч.* Өзлексез хәрәкәт итеп торган берәр төрле массаның аерымланып чыккан өлеше. *Ул учаклар атна буе янды, төннәрен ялкын телләре йолдызлар тәненә кадәр менеп җитәдер сыман тоелды.* М.Кәбиров

24) *күч.* Нинди дә булса предметның укны хәтерләтә торган озынча һәм очлы детале. *Римский-Корсаковның --- Кар кызын уйнаган чакта, үземне нәни бер кыз итеп сизә башлыйм, хәтта, --- әкият тылсымына бирелеп, күккә ашкандай булам, әгәр шул чакта мине үлчәүгә салып карасалар, билләһи, үлчәү теле бернәрсә дә күрсәтмәс кебек...* Р.Вәлиев. *Ә теге вакыт дигән сәгатьнең телен алга күчерәбез: син тереләчәк көннәр тизрәк якынаерлар.* Н.Гыйматдинова

◊ **Тел ачкычы** 1) Кирәкле урында, вакытта ачык, матур итеп сөйли алу куәсе. *Кая китте соң Альфредның тел ачкычы, кызлар янында ул беркайчан да аптырап калмый иде ләбаса!* Ф.Садриев; 2) Укырга-язарга өйрәнергә ярдәм иткән нәрсә. *Тукайның «Су анасы» китабы тел ачкычы булып, хәреф танырга өйрәнгән Әмир инде «зуп-зур» Еники булгач та Тукайны кулыннан төшерми.* Р.Идрисов. **Тел ачтыру** 1) Кечкенә балаларны сөйләшергә өйрәтү, сөйләшә белү сәләтен булдыру. *Баланың зиһенен, хәтерен үстерер өчен, тел ачтырыр өчен, --- борынгы бабаларыбыз-әбиләребез әкият уйлап чыгарып, шул әкиятләрне нарасыйларга сөйләү йоласын барлыкка китергән.* Р.Вәлиев; 2) Нинди дә булса яшерен серне ачарга, сөйләп бирергә мәҗбүр итү. *Менә шушы күзгә-күз очраштырудан соң да берни чыкмагач, гестапочылар Ефимовның кулларын артка каерып бәйләп, «тел ачтыру» камерасына яптылар.* Г.Әпсәләмов. **Тел ачу** 1) Баланың беренче сүзләрне әйтергә тырышуы һәм әйтә башлавы. *Бишек җыры балага милли хис сала, телен ачуга юл ача.* И.Таһиров; 2) Балага ана телен яхшы итеп үзләштерергә ярдәм итү. *Алтмышынчы елларда телсез калган татар балаларының телен ачкан шагыйрь ул [Шәүкәт Галиев].* Р.Миңнуллин; 3) Сөйләшүчән итү, сөйләргә дәрт бирү. *«Аңымны яктырткан, телемне ачкан илаһи көчләрнең фәрештәләр булуын абайламаганмын ул вакытта», – ди абыстай.* Л.Кәшфиева; 4) Сөйли башлау, сөйләргә керешү, әйтеп бирү. *Моннан соң нәүбәт кызга калгач, кыз дәхи үз тарафыннан былбыл кебек фәсыйх телен ачып әйтте.* К.Насыйри; 5) Нинди дә булса серне, яшерен сүзне әйтеп, сөйләп бирү. *Кызның бу хакта безгә тел ачканы юк әле.* М.Хуҗин. *Хәер, бу хакта аның берәүгә дә тел ачканы юк, ышанмасларын белгәнгә сөйләми.* Ф.Җамалетдинова. **Тел ачылу** 1) Бала сөйләшә башлау. *Улын теле ачылу белән абыйсы һәм апасына «зур әти», «зур әни» дип әйтергә өйрәтте.* З.Кадыйрова; 2) Бик ачык, матур итеп сөйли башлау. *Сөйләшмәгән чагындагы таләпләрен аңламаганга салышып булса да, теле ачылгач, сүзен ишеттерерлек итеп әйтә башлады.* Ф.Яруллин; 3) Күп сөйләшүчән, җор теллегә әйләнү, сөйләргә сүз табу. *Баштарак чит-ят кешеләр шикелле аз сөйләшеп кыенсыныбрак барсалар да, тора-бара телләре ачылып китте.* З.Мурсиев. **Тел әйләндерү** 1) *к.* **тел кашу**. *Гөлзифа керде дә: «Хәлләр бер көе», – дип, бушка тел әйләндереп утыра.* Р.Төхфәтуллин; 2) Авыз ачып сүз әйтү. *Тел әйләндерер чамасы калмады.* К.Тимбикова. **Тел әйләнмәү** 1) Аңлаешлы, ачык итеп әйтә алмау. *Урыччага тел әйләнми безнең...* Ф.Баттал. *Менюдагы ризыкларның тел*

*әйләнмәс исемнәрен укыгандай итте Шәүкәт, кайсысы нәрсә икәнен чамалый алмый гаҗиз булды, тирләп чыкты хәтта.* К.Кара; 2) Берәр төрле авыр эш, хәл, хәбәр һ.б.ш. әйтергә уңайсызлану, әйтергә кыймыйча тыелып тору. *Ниндидер җанлану бар да кебек, әмма шулай да, эшләр яхшыга таба бара, дип әйтергә тел әйләнми.* Р.Мөхәммәдиев. *Гомер буе дигәндәй колхоз идарәсендә җыештыручы булып эшләп, ике ел элек кенә лаеклы ялга чыккан кешене, ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, дип әйтергә тел әйләнмәс.* Ә.Әминев. **Тел әйтү** *к.* **тел сөйләү** (*1 мәгъ.*). *Мәмәткол мулла ничек булса да ычкынып качып бара икән, янә өстебезгә тел әйтер дип, артыннан килеп үтергәннәр.* К.Насыйри. **Тел әрәм итү** Файдасызга сөйләп аңлатырга тырышу. *Сөйләмә, атасы, тел әрәм итеп, мыскыл итәргә чакырганнар безне монда!* Ф.Баттал. *Тел әрәм итеп торасы да юк, аңлый торган кеше түгел бу.* Аманулла. **Тел баглану** *к.* **тел бәйләнү**. *Башкалар, урыннарыннан сикереп торып, аның янына җыелышканда, Зыяда җан әсәре калмаган: тыны киселеп, теле багланган; кул вә аяклары ике якка җибәрелгән, йөзе үлем аклыгы белән капланып, күзләреннән хәят очкан иде.* Г.Ибраһимов. **Тел бармау** Нинди дә булса сүзне яки фикерне әйтергә кыенсыну, әйтә алмый тору. *Минем, Хәнәфи абзыйның сүзен юкка чыгарып, аны да рәнҗетәсем килми, шулай ук ялганларга да тел бармый иде.* Г.Бәширов. **Тел батырып сүз әйтү** Кискен итеп каршы әйтү. *Җыйналган халыкка тел батырып сүз әйтә алмыйсың.* А.Вергазов. **Тел бәйләнү** Оялу, тартыну, каушау, курку һ.б.ш. кичерешләр нәтиҗәсендә сүзне әйтә алмый тору. *Әллә ни каушамадым да шикелле, ә шулай да миңа тел бәйләнде.* Ә.Еники. **Тел бәйле** Нәрсәне дә булса әйтергә ярамый, әйтә алмый (хакы юк яки курка). --- *комиссарның төнге очышта бүтән йомышы да бар иде шул. Тик бу хакта Ләйләгә әйтергә тел бәйле...* Ш.Рәкыйпов. **Тел белән әйтү** Күңелдәге фикерне, уйны сүз белән белдерү, сөйләп бирү. *Зөһрәдән, чыннан да, тел белән әйтеп булмый торган үзенә бертөрле садәлек бөркелеп тора иде кебек.* М.Хәсәнов. *Аппак аның үзенең дә күңелен борчыган, әйтергә кыюлыгы гына җитмәгән нәрсәне тел белән әйтеп бирде!* Н.Фәттах. **Тел белән ертык ямап булмый** «Сүз сөйләүдән файда юк» мәгънәсендә. **Тел белән тегермән кору** *к.* **тел белән тегермән тарту**. **Тел белән тегермән тарту** Эшләгән эше булмаса да, бик булдыклы булып сөйләнү. *Әлеге крепость алырдай булып кыланган буш куыклар, кулыннан килмәгәч, күбрәк тел белән тегермән тарту юлына баса.* С.Поварисов. **Тел белән телү** Бик үткен, ачы итеп әйтү, сөйләү. *Һәр җөмләсендә тел галиме булуын сиздерә, талканын коры тота бу [Л.Җәләй]. Сүз белән сөзеп, тел белән телеп тә ала.* И.Низамов. **Тел белән тетү** *к.* **тел белән телү**. *Шуннан мин тиргәнергә тотынам. Күңелдән ул кадәр ачу килмәсә дә, тел белән тетеп салам.* М.Әмир. **Тел белән чумар ишү** *к.* **тел белән тегермән кору**. *Берсендә, ничектер, тел белән чумар ишүче булдыксыз түрәләр турында сүз чыкты.* И.Низамов. **Тел беркетү** Сүз куешу, вәгъдәләшү. *Бер ау эзенә төшкән ике аучы эзәрлекләнүчегә каршы тел беркетмәве мөмкин түгел.* М.Гайнетдин. **Тел бирәне** *гади с.* Күп сөйләүчән, күп сөйләргә ярата торган кеше. *Тагын бер тел бирәне: – Кызыл туй ясарбыз, – дип тә өстәде.* М.Әмир. **Телгә алу** Искә төшереп сөйләү, сүз барышында игътибарга алып сөйләп, әйтеп китү, кемне, нәрсәне булса дә сөйләү темасына кертү. *Мәгәр, Миңлենисаның эш сөюе, каралты-кураны тәртиптә тотуы турында гел сокланып, хуплап телгә алалар.* В.Имамов. **Телгә алыну** Сүз уңаенда әйтелеп китү. *Су анасының балтырына төшкән озын чәче, алтын тарагы да телгә алынды.* Г.Бәширов. **Телгә батыр** *к.* **телгә чая**. *Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...* Ә.Еники. **Телгә беткән** Сүзгә оста, телдәр. --- *үзен бик телгә беткән, мәзәкка бай, диләр.* С.Шәрипов. **Телгә җор** *к.* **телгә чая**. *Телгә җор, тиешле сүзне вакытында таба, әйтә белә.* М.Мәһдиев. **Телгә йозак салу** Сөйләргә ирек бирмәү, сүздән тыю, сүз бирмәү. *Өендә амбар кенәгәсе тота, гел болай бармас бу дөнья, телләргә йозак салыныр дип, хәтәр сүзләрне шунда теркәп бара иде.* М.Галиев. *Телгә йозак салып буламы, Ямат ага.* М.Хәбибуллин. **Телгә кертү** Гайбәт тарату. *Бәлки, әле ул чакта ук телгә кертәсе калмагандыр? Әйткән сүз үрчемле була, ди бит.* Ф.Җамалетдинова. **Телгә керү** 1) Яманаты чыгу, гайбәт таралу. *Минем янымда ирем – Рифкатем бар, гайбәтмазар миңа йокмый. Әнә ирсез Идрисова янында буталсаң, хәзер телгә керерсең.* И.Нәбиуллина; 2) Танылу, мәшһүр булып китү. *Озакламый халык арасында Габдулла Ходаяровның, «алтын куллы» күз хирургы, мең дә берне белә торган табиб, дигән исеме телгә керә.* Т.Әйди; 3) Ызгышу, әрләшү, кычкырышу. *Аның белән телгә кермәвең, аның кыңгыр эшләренә күз йомып кала белүең мең мәртәбә кыйбат.* В.Имамов; 4) Сөйләнү, әйтелү. *Мәзиннәрне саташтыра торган «шайтан таңы» дигән нәрсә телгә кергән.* А.Тимергалин. **Телгә килү** 1) Сөйләшми, эндәшми торганнан соң сөйли башлау. *Беркавым сүзсез карашып торгач кына, Хәлиулла абый телгә килде.* Р.Галиуллин; 2) Кинәт кеше кебек сөйли башлау. *Якынрак баргач, бөркет телгә килеп әйтә: – Син мине атма, алып кайтып ашат, тәрбиялә, мин синең берәр кирәгеңә ярармын.* Әкият; 3) Ара бозылу; сүзгә килү. *Соңрак авылдашлары белән телгә килгән вакытларда, аны әлеге ирексездән кылган кәсебе өчен хурларга торучылар да булгалады.* Ә.Гаффар; 4) Эшли, хәрәкәт итә башлау. *Ләкин тәннәре белән җирнең дерт итеп куюын тойдылар. Немец пушкасы телгә килде.* Х.Камалов. **Телгә маһир** *к.* **телгә чая**. *Телгә маһир Ханбәк, чәй эчә-эчә, сүзен дәвам итте.* С.Шәрипов. **Телгә оста** *к.* **телгә чая**. *Йодрык кадәр генә булса да, телгә оста икән малай актыгы.* В.Нуруллин. **Телгә чая** Оста сөйләүчән. *Телгә чая штурвалчы кыз Җәмилә үзе юкта Мидхәт агайны мыеклы түти дип йөртә...* С.Сабиров. **Телгә шәп** *к.* **телгә чая**. *Дәгъвалыйсың, сүзгә шәп тә телгә*

*шәп*. Г.Тукай. **Телдән йозак төшү** Ачыктан-ачык әйтү мөмкинлеге барлыкка килү. *Телдән йозак төшкән чак*. Р.Зәйдулла. **Телдән калу** Тирән эчке кичерешләрдән яки көчле авырудан сөйли алмый башлау, сөйләү сәләтен югалту. *Ишегалдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын!* Г.Бәширов. *Ерак юлларда адашып, кара төннәрдә саташып, төшләнеп беткән, телдән калган сырхау, бәхетсез кеше итеп тойды ул үзен*. А.Гыйләҗев. **Телдән тарту** Нәрсә булса да әйтергә, сөйләргә мәҗбүр итү. *Теленнән тартмады бит ул аның, ялынып әйттермәде*. Җ.Дәрзаман. **Телдән ташламау** *к*. **телдән төшермәү**. *Аксаби карт соңгы сулышына чаклы аны [Әнисәне] теленнән ташламады*. З.Бәшири. **Телдән телгә** Бер сөйләүчедән икенче сөйләүчегә. *Аның бу тансык сүзләрен телдән телгә сөйләп, такталарга язып, калалардан калаларга күчә-күчә күтәреп йөриләр*. М.Хәбибуллин. *Үрнәк итеп телдән телгә сөйләделәр*. А.Нәҗми. **Телдән төшермәү** Һәрвакыт искә алып сөйләп тору. *Исемеңне теленнән төшермичә, бисмилла урынына кабатлап көтте*. Т.Галиуллин. *Ә бит Сания теленнән төшерми мактаган Рауза кайчандыр аның, Нәгыймәнең килене буласы кыз иде!* А.Әхмәтгалиева. **Телдән төшмәү** 1) Һәрвакыт сөйләнеп тору, еш телгә алыну, онытылмау. *Әмма телдән төшми торган кушаматы «Мөштек» иде*. В.Имамов. *Туй төшкәндә күчәреннән чыккан тәгәрмәч вакыйгасы вакытлар үткәч тә бик озак авыл кешеләре теленнән төшмәде*. З.Мәхмүди; 2) Әйтелмәү, әйтелми калу. *Бу гүзәлне юатырга теләп, аның күңеленә матур-матур сүзләр килде, тик алар берсе дә теленнән төшмәде*. С.Зыялы. **Телдән төшү** Халык арасында йөргән берәр төрле тема, вакыйга, предмет, кеше һ.б.ш. онытылу, сөйләнми башлау; кулланылмый башлау, кулланыштан туктау. *Сүзне сабый кабатласа, Бәладән тел котылыр. Телдән төшкән тел юк булыр, Телдәге тел нык булыр*. Р.Бикбаев. **Телдән утлар чыгару** *к*. **тел белән тегермән кору**. *Фәрдәнә ачуланырга дигәндә кимен куймый, кулыннан әллә ни эш килмәсә дә, теленнән утлар чыгара ул*. Х.Камалов. **Телдән ычкыну** Урынсызга кирәкмәгән яки бик үк әйтергә ярамаган сүзне ялгыш әйтеп ташлау. *Күңелендә җыелып сакланган сүзләре аңа буйсынмыйча, теленнән ычкындылар*. Ә.Баян. *Теленнән ялгыш сүз ычкынып китүе бик мөмкин*. С.Зыялы. **Телдән язу** *к*. **телдән калу**. *Кызының бу сүзләрен ишеткәч, Галәветдин агай лып итеп кәнәфигә утырган да шактый вакыт теленнән язып торган*. В.Нуруллин. *Сабый берни әйтми, әйтә алмый, чөнки телдән язган*. А.Тимергалин. **Теле авызына сыймау** 1) Сүзне уйлап тормыйча юк-бар сөйләү; әдәп сакламыйча әйтү. *«Телең коргыры! Нәрсәгә кирәк булды соң сиңа «установкасы белән» дигән булып лыгырдап эшне буташтырырга, телең авызыңа сыймады бугай», – дип --- үз-үзенә ачуы килде*. Ш.Камал; 2) Сер саклый алмау. *Теле авызына сыймаган кешедә бәла бар*. Мәкаль. **Теле бәйле** 1) Нинди дә булса кичерешләрдән сүзен таба алмый, сүз әйтә алмый тору. *Аңлатырга табалмыйм бер матур сүз, Телем бәйле – бәхетем итте һушсыз!* Р.Гаташ; 2) Нәрсәне дә булса әйтергә хакы юк, сөйләргә ярамый, тиеш түгел. *Ант белән телен бәйләп куйган бу адәмнән башкасын сорашып та, белешеп тә булмый иде инде*. Ф.Латыйфи. **Теле белән тере агачны корытыр** Явыз, зәһәр телле кеше. **Теле йозаклы** Берәр нәрсәне әйтергә хакы юк, бер сүз дә әйтә алмый. *Күңелебез тозаклы, телләребез йозаклы дигәндәй, безне кемнәр күрсеннәр дә кемнәр белсеннәр?* Т.Гыйззәт. *Әмма яшьлек мәхәббәте, беренче мәхәббәте каршында аның да теле йозаклы иде*. С.Поварисов. **Теле кору** 1) Сүз әйтә алмаслык хәлгә килү. *– Илнең өлкән агасына мондый сүзне әйтә алган телең корыр! – диделәр*. Г.Ибраһимов; 2) **телем корысын** Ант итү сүзе. *Ватаныма һичкайчан һәм һичкайда хыянәт кылмаска ант итәм. Моның киресен эшләсәм, бу сүзләрне әйткән телем корысын*. Г.Кутуй. **Теле корышу** *к*. **теле кору**. *Хатыным авырый, дип килеп әйтсәң, телең корышыр идеме?* А.Гыйләҗев. **Телен аркылы тешләү** 1) Каршылык күрсәтмәү, каршы сүз әйтмәү. *Аны кече яшьтән үк, ризасызлыгыңны тышка чыгарма, телеңне аркылы тешләп булса да түз, дип өйрәттеләр*. М.Әмирханов; 2) Теләсә нинди авырлыкларга, газапларга да түзү. *Ләкин тормыш киртәләре алдында җебеп төшмәде, телен аркылы тешләп булса да түзде, ыңгырашмады, сыкранмады*. Ә.Рәшит. **Теленә баш була алмау** Артык күп сөйләү. *Хәбирәттәй, чыгып китмәкче булып, әле ишек токкасына тотынды, әле яңадан күршесе янына килеп утырды, һаман теленә баш була алмыйча, тегесен искә алды, монысын искә алды*. Н.Фәттах. **Теленә йозак салу** Сөйләүдән туктап калу, үз-үзен сүздән тыю, әйтүдән тыелып калу. *«Балалы, ирле хатыннарны юлдан яздыру буенча син белгеч», – дип авызын томалыйсы килү кытыклавы миеннән узса да, теленә йозак салуны мәгъкульрәк күрде*. Т.Галиуллин. **Теленә салыну** *к*. **теленә салышу**. *[Хаҗия:] Житәр, телеңә салынма*. Т.Гыйззәт. *[Һади:] Телеңә салынма! Әйрән җылына*. Д.Салихов. **Теленә салышу** Карышу, каршы әйтү; телләшеп, кушылганны үтәүдән качырга тырышу. *Тырыш егет шапырынмый, һаваланмый, теленә салышмый, тыныч кына үз эшен җиген-җиккә китереп башкара*. Б.Камалов. **Теленә тилчә төшкере** Әйткән берәр начар сүзгә каршы ачуланып җавап бирү сүзе. *Телегезгә тилчә төшкән нәрсәләр! Үзебезгә генә тел тиерүегез җитмәгән иде, инде динебезгә дә тел тиерә башладыгызмыни?* Г.Камал. **Теленә тилчә чыккыры** *к*. **теленә тилчә төшкере**. *--- колхоз рәисе Сәлмән Сәлимечнең урта мәктәпне алтын мидәлгә тәмамларга җыенган кызы --- көтүче Фәхринең тракторчы малае белән типтерә, имеш. Тфү, телеңә тилчә чыккыры!* Ф.Имамов. *«Телеңә тилчә чыккыры!» дип куйды карт күңеленнән генә*. Ф.Абдуллин. **Теленә чуан төшкере** *к*. **теленә тилчә төшкере**. **Теленә чуан чыккыры** *к*. **теленә тилчә төшкере**. *Татарда юмор юк, дип әйткән кешенең теленә чуан чыксын, чөнки ул хаксыз!*

Э.Фатыйхова. **Теленә шайтан төкергән** Телгә оста, телләшергә бик үткен. *Гафу ителмәслек хәл: мин, бүтән чакта телемә шайтан төкергән күп сүзле малай, телсез-өнсез калган идем.* З.Хөснияр. **Теленә эләгү** *к.* **телгә керү** (*1 мәгъ.*). *Үзише аксөяк бикәләр дә аның тоздан да әче теленә эләгүдән шүрләп торалар.* М.Әмирханов. *Шулай шул, кеше теленә бер эләксәң, элеп тә алалар, селкеп тә салалар.* Г.Галиева. **Телен белү** Нәрсәнең дә булса хикмәтен, рәтен белү, серен, эчке хасиятен аңлау, тәртибен төшенү. *Һәр эшнең телен белергә, серен тоярга кирәк...* М.Хәсәнов. *Җирнең аның телен белергә кирәк, исен сизәргә...* Н.Фәттах. **Телен йозакта тоту** Сер саклый белү. *Наташа да Әлфиягә ләм-мим сүз әйтмәде. Телен йозакта тота белә икән.* Т.Галиуллин. **Телен йоткандай булу** *к.* **телен йоту**. *Артык дулкынланудан, ышанып һәм якын итеп сөйләшүдән кунак телен йоткандай булган иде, ул бары тик баш кына селки алды.* Р.Мирхәйдәров. **Телен йоткан шикелле булу** *к.* **телен йоту**. *[Таран] Телен йоткан шикелле тәмам сүзсезләнеп, йомылып-басылып калган.* Н.Исәнбәт. **Телен йоту** 1) Берни дә дәшмәү, сөйләшмәү. *Әллә куркудан телеңне йоттыңмы?* А.Гадел; 2) Нәрсәгә дә булса таң калып тынып калу. *Зур, авыр, сырлап-бизәп ясалган ишек тавышсыз-тынсыз гына ачылып киткәч, Әхмәдулла хәзрәт телен йота язды.* Татар әдипләре; 3) Искиткеч тәмле, ләззәтле булу, күңелгә хуш килү. *Токмачлы шулпа шундый тәмле, телеңне йотарсың. Әни мәрхүмә шулай тәмле итеп пешерә иде токмачлы ашны.* И.Салахов. **Телен корыту** Кемне дә булса сөйли алмаслык хәлгә китерү, ни дә булса сөйләүне туктату. *Тизрәк очына чыгасы иде, гайбәт телләрен тизрәк корытасы иде.* Ә.Касыймов. **Телен кыскарту** Күп сөйләүдән тыю, чамалап, сакланып кына сөйләргә мәҗбүр итү. *Заркент хуҗасының гаебен тануы, тәүбә итүе республикада күпләргә ошамады, ике тапкыр йортына ут төртергә маташтылар. Бу аңа «телеңне кыскарт» дигәнне аңлатырга тиеш иде.* Р.Мирхәйдәров. **Телен табу** *к.* **телен белү**. *Менә шушы «илаһи рух» аша Заһид һәр көйнең үзенә хас телен табарга, музыкадагы тирән серләрне йөрәге белән тоярга, милли рухта булган гармонияләрне, үзенчәлекле алымнарны тотып алырга тырыша.* Ш.Рахманкулов. **Телен ялау** Ашарга теләп ымсыну. *Борынын тәмле өчпочмак исе кытыклап алгач, малай үзе дә сизмәстән телен ялап куйды.* Көмеш кыңгырау. **Теле озын** Теләсә ни сөйләп йөрүчән, гайбәт таратырга оста; теләсә ничек җавап бирә торган. *Кулыннан эш килмәгән кешенең теле озын була шул!* М.Маликова. **Теле телгә йокмау** Тиз һәм бик оста, шома сөйләү. *Телләре телгә йокмый, мактапмымактыйлар товарларын.* Д.Бәдриев. **Теле тигәнәкле** *к.* **теле төерле**. **Теле төерле** Мәкерле, энчекерле сүзләр әйтүче, явыз киная белән сөйләүче кеше. *Дошман теле төерле, айкый гына күңелне.* Мәкаль. **Теле чыгу** 1) *к.* **тел ачылу**. *Бәс, мин, яңа теле чыга торган баланың аңлашылмас такмагы кеби, вәзенсез-нисез бер бәет такмакларга керештем.* Г.Тукай; 2) Үз фикереңне ачыктан-ачык курыкмый әйтә башлау. *Рәхәткә чыдаша алмыйсыңмы? Телең чыга башладымы? Миңа сине --- ничәмә ел шундый зур урында, йомшак кәнәфидә утырткanга рәхмәтең шулмы?* Г.Мирһади. **Теле шомару** Сүзгә чая, оста булып китү. *Дөресрәге, күбрәк Нурислам сөйләде, чөнки аның тормыш тәҗрибәсе дә байрак, әйтер сүзләре дә күбрәк, теле дә шомарганрак иде.* Р.Вәлиев. **Тел кагу** 1) Тел шартлату, чөңгерү. *[Симез аты] Шулкадәр кызу бара: мөмкин түгел Акыртын барган өчен тел кагарга.* З.Бәшири; 2) Каршы сүз әйтү; сүз белән җәберләү, тел тидерү. *Фатыйма карчык, Вәлинең, үзенә каршы тел каксалар, кара көеп йөрү гадәтен белә иде.* С.Рафиков. **Тел кайтару** Телләшү, каршы җавап бирү. *Әле үземезнең асрау гына, кем булган соң инде, шул да абыстасының сүзенә тел кайтарып, ирек бирсәң, оршышмакчы булып тора инде.* Г.Исхакый. **Тел кату** 1) Тәкъдим ясау, өндәү, сүз кушу, сүз салу. *Тик ул берсенә дә тел катмады, кулын салмады. Горур, гарьчел, әхлакый тотнаклы кеше иде Ярулла карт.* Т.Галиуллин; 2) Начар сүз әйтү, тел тидерү. *Сүзләрең затлы булсын, Телләрең татлы булсын, Каты тел катма, улым, Тәмсез сүз әйтмә, улым.* К.Булатова. **Тел кашу** Урынсызга ярамаганны сөйләү, сөйләнү; гайбәт сөйләү. *--- һәммәсе, күзен алартып, иртәдән чиратка тезелгән, ә мондый җирдә тик торганнан тел кашырга яратучылар тыныч утыра алмый инде ул.* Р.Мулланурова. **Тел көрмәкләнү** 1) Авыз мускулларының хәлсезлеге яки параличы һ.б.ш. сәбәпләрдән сөйләшү, гомумән сүзләрне әйтү кыенлашу. *Нишләп тавыш чыкмый соң, тел көрмәкләнгән, уң як бернәрсәне тоймый...* Д.Гыйсметдин; 2) Каушау, дулкынлану, курку һ.б.ш. хисләр нәтиҗәсендә сүз әйтә алмый тору. *– Инде иялэштем, тел көрмәкләнми хәзер, – диде дә, тыйнак кына кычкырып көлеп алды Рафаэль.* Р.Мөхәммәдиев. *Тик сүз әйтергә дип авызны ачам гына, баштан бар белгән юньле фикер чыгып очкан була, тел көрмәкләнә.* Татарстан яшьләре. **Тел көрмәлү** *к.* **тел көрмәкләнү**. *Бу юлы хәмер үзенекен итте: аның моңарчы нурланып торган чиста зәңгәр күзләре тоныкланды, хәрәкәтләре салмакланды, хәтта теле дә көрмәлә башлады.* В.Нуруллин. **Тел кузгату** Белдерү, уйлаган сүзен әйтү. *– Мәлик Әшрәфнең башын чаптырмый кайтмыйм, әткәй, – дип тел кузгаткан Бирдебәкне хан ярты сүздә бүлде.* В.Имамов. **Тел күнү** 1) Иялэшү, үзләшү, якынаю. *--- тел күнмәгән килеш, җиде ят кешегә ничек әни дип әйтергә кирәк соң?* А.Алиш; 2) Авазларны дөрес яңгырату, дөрес әйтергә өйрәнү. *Корьәнне яшь балалар аңлап укымыйлар, бары гарәпчә тел күндерү өчен укыйлар.* Г.Баруди. *Булмый, тел күнми шундый ят сүзләргә.* Н.Фәттах. **Тел күтәрелү** Кемгә дә булса начар, әшәке сүз, ярамаганны әйтә алу. **Тел күтәрү** Кемгә дә булса каршы әйтү, әйтергә тиеш булмаган сүз әйтү. *Атаңа каршы тел күтәрә башладыңмы, җирбит?!* В.Имамов. **Тел кыймылдату** Нинди дә булса мәсьәлә турында сүз әйтү, сүз башлау. *Кайбер кемсәләргә тел кыймылдату да кирәк*

*булмас иде, сиздер генә, атын үзе үк Аксайга илтеп бирер, Арипов белән бер табын янында утыруны дәрәҗә санар иде әле.* Р.Мирхәйдәров. **Тел кычыту** 1) Нәрсә дә булса әйтәсе килү теләге көчле булу, әйтеп калырга теләү. *Аның белән бәхәсләшәсе, әйткәләшеп аласы килә, тел кычыта башлый.* Р.Миңнуллин; 2) Кирәкмәгәнне, артыгын күп сөйләү. *Кайберәүләр, телләре кычытканга түзә алмыйча, күңелендәгене бөтенләе белән чыгарып аудара иде: – Элек синең җиңгән Анна исемле булган, ди, әйеме?* Г.Бәширов. **Телләр аерылу** Уртак фикердән тайпылып, бер-береңне аңламый башлау. *Карчык салкын гына тавыш белән: – Урманнан киләсеңме, тегермәннәнме? – диде. Бу сорау мине аяктан екты. Безнең телләр аерылды булса кирәк.* Ф.Кәрим. **Телләре бер** 1) Бер-берсе белән киңәшеп эш итү, уртак фикердә булу; 2) Берсе икенчесеннән аерылмый, икесе дә бер. *Елан белән баканың теле бер.* Мәкаль. **Телне бәйләү** 1) Әйттермәү, сер итеп сакларга мәҗбүр итү. *Шаһлар телне бәйләп тота алырлар.* Дастан. *[Тик] Тормам, минем телемне бәйләп куя алмассың!* Г.Камал; 2) Билгеле бер эчке тойгы, хис, кичерешләр һ.б.ш. әйтәсе килгән сүзне әйтергә комачаулау. *Әйтәсе сүзенең зурлыгы һәм мөһимлеге аны, ничектер, авыр йөк сыман басып тора, телен бәйли һәм йөрәген дөп-дөп тибәргә мәҗбүр итә иде.* М.Галәү. *Ничәмә-ничә тапкыр омтылып карады ул аңа мәхәббәттә аңлашырга, тик берничек тә булдыра алмады. Ниндидер сәер көч телен бәйли дә куя!* З.Мәхмүди. **Телне кыска тоту** Әйтәсе килгән сүзне әйтмичә тыелып калу. *Адәм заты начарлануга тормыштан күп мисаллар китерергә булыр иде. Ләкин, телеңне кыска тоту яхшырак дип, эчтән үзләрен тыйдылар шикелле.* Х.Камалов. **Телне сындыру** Сүзнең әйтелеше авыр булу. *Мылтыкларын гына күрсәң дә искитәрлек, исемнәре генә дә ни тора, телеңне сындырырлык, билләһи.* Р.Мирхәйдәров. **Телне теш артында тоту** Әйтергә ярамаганны әйтмәү, уйлап сөйләшү, сер саклый белү. *Шулай ук минем турыда да сүз куертасы булма. Телеңне теш артында тотуың хәерлерәк булыр.* М.Хәсәнов. **Телне тешләү** 1) Куркып яки уңайсызланып, сөйләүдән тыелу, сөйләп торган сүздән кинәт тукталу. *[Әсирләр] --- маңгайларына автомат терәгәч, телләрен тешлиләр һәм селкенмичә яталар.* Г.Әпсәләмов; 2) Гомумән сөйләшмәү, тынлык саклау. *Хәйрулла телен тешләгәндәй тынып калды.* В.Нуруллин; 3) Нинди дә булса сүзне әйттерергә тырышсалар да, эндәшмәү, сүз әйтмәү, сер саклау. *Ни генә булмасын, телеңне тешлә, минем белән танышлыгың, башка дусларың хакында ләм-мим!* Р.Мирхәйдәров; 4) Теләсә нинди авырлыкка түзеп тору, риза булу. *Ярар сүзен гел кабатлап, җиңелгәнеңне сиздереп, башыңны иеп, телеңне тешләп яшәсәң генә инде...* Ф.Дәүләтбаев. **Телне тыю** 1) Әйтәсе сүзне, әйтергә ярамаганны яки килешмәгәнне исәпкә алып, аңлап эндәшми, әйтми калу. *Оста барында кулыңны тый, мулла барында телеңне тый, дип кисәтә-кисәтә тәрбияли иде безне өлкәннәр...* В.Имамов. *Хәлсез ана да, аның борчулы улы да, Ходай Тәгаләгә караган кебек, бер сүз эндәшми-нитми карап утырдылар... Ләкин, телне тыйсаң да, уйларны тыеп буламы соң?!* Г.Гыйльманов; 2) Кемгәдер карата каршы, начар сүз әйттермәү, сүз әйтергә ирек бирмәү. *Син телеңне тыя беләсеңме?!* М.Кәбиров. **Телне чыгарып** Соң дәрәҗәдә арып, тәмам хәлдән таеп. *Көне буе урамнан кайтып кергән юк, телең чыгардай булып арылган. Инде күзләрең дә йомылып, йоклап та барасың.* Г.Бәширов. *Куштаннар команда белән, телләрен чыгарып, Гафелне куып йөри.* Р.Батулла. **Тел озайту** *к.* **тел тидерү**. *Бигрәк тә бу гасырның башында төрле кара көчләр сөекле Пәйгамбәребезгә тел озайтып, --- төрле начарлыкларны мәйданга чыгарырга тырыштылар.* М.Басыйр. **Тел озату** *иск. к.* **тел озайту**. *Мин һәммә ислам газитәләрен җаным кадәр сөямен, һичберсенә тел озату минем шәэнем түгелдер.* Г.Тукай. **Тел очына килү** Тиешле урынында әйтеләсе сүзләр искә төшү, хәтергә килү; әйтәсе килү. *Стиль башка, сүзләр запасы, лексикон башка, кирәкле сүзләре, терминнары тиз генә тел очына килми...* Р.Миңнуллин. **Тел очында** 1) Әйтеләсе сүз алдан әзерләнгән булу, әйтергә теләгән сүз күңелдә тору. *Классташларыма рәхмәт, күз карашларында һәм тел очларында олы сорау билгесе сизелеп-күренеп торса да, ник берсе төнге вакыйгалар турында төпченсен.* А.Тимергалин; 2) Әйтәсе сүзне искә төшерә алмый тору. --- *аты коргыры, тел очында гына тора.* Р.Галиуллин. **Тел өстендә** Һәрвакыт гайбәт һ.б.ш. темасы булу, еш телгә алыну, һаман сөйләнеп тору. *Кыз язмышы кыл өстендә, Кылдан төшкәч тел өстендә.* Мәкаль. **Тел пычрату** Ямьсез, күңелгә ятышсыз сүз сөйләү. *Әмир Ибраһим Рахман белән сүз алышып тел пычратырга да теләк белдермәде.* В.Имамов. **Тел саклау** Хөрмәт йөзеннән яки йола саклап күп сөйләшмәү, дәшмәү, тел яшерү. *Козьманың пәһлевандай таза гәүдәсе үк әртил ирләреннән тел саклауны сорый, анналары аның гаделлеге дә аларны буйсынырга мәҗбүр итә иде.* В.Имамов. **Тел салу** Берәр төрле үтенеч белән яисә катлаулы, четерекле мәсьәләне кузгатып сүз әйтеп карау. *Бу хакта мин әле тагын бер-ике кешегә тел салып карамакчы булам.* Ак юл. **Тел салындыру** Бик нык ару, талу, талчыгу. *Кайтасың тел салындырып, тәмам эт булып арып.* Ш.Галиев. *Көн саен иртүк килеп берничә сумка китап төйибез дә шәһәр буйлап тел салындырып йөрибез.* М.Нурулла. **Тел сату** Сүз ташу, гайбәт сату. *Ярый әле хатыны тел сатучы түгел, сүзне урамга чыгармый.* Ф.Яхин. **Тел сөйләү** 1) Әләкләү. *Фазыйл мәгъзүм атны мактады, сары башлы малай минем өстемнән тел сөйләде: – Без, ялан карап йөреп, сезнең борчак эченә хәл җыярга утырган идек, улың безгә бәйләнә, – ди.* Г.Ибраһимов; 2) Гайбәт сөйләү. **Тел сөяксез** «Юк-барны да, ялганны-чынны да сөйләргә була» мәгънәсендә. *Сүләсен, сеңлем, сүләсен. Тел сөяксез бит. Син аңа бер дә аптырама.* Р.Кәрами. **Тел сузу** *к.* **тел озайту**. **Тел табу** Үзара аңлашу, бер-береңне аңларлык сүзләр табу, килешү, уртак

фикергә киләә алу. *Мәҗлес таралгач, Хөрмәт аны [Мәнвияне] озатып та куйды, телен тапты, ләкин бүз көясе булмады – озак тоткарламады.* Р.Кәрами. **Тел таптау** *к.* **тел юкарту**. *Карышмыйм, барам, әмма ләкин телеңне таптама, зинһар.* Ф.Хөсни. **Тел тегермәне** Күп итеп кирәкмәгән, урынсыз, мәгънәсез сүз сөйләү турында. *Фатыйманың тел тегермәне әйләнешен арттыра барды.* Ф.Садриев. *Аның каравы тел тегермәненең суын таштырып-таштырып тутырган: сөйләп туя алмый.* Н.Гыймматдинова. **Тел тешләү** Сүз сөйләүдән тыелу, каршы сүз әйтмәү. *Алар үзләре дә урлашалар, шуңа күрә тел тешләп яшәүне артыграк күрәләр.* Ф.Баттал. **Тел тибрәндерү** *к.* **тел тибрәтү**. *Егетнең акылы түгел, ташып чыгарга торган хисләре шушы рәвешле итеп телен тибрәндерде.* Ф.Яхин. **Тел тибрәтү** Сөйләү, сүз әйтү. *Ул тел тибрәтеп нидер сорамакчы булды – тавышы чыкмады.* М.Маликова. **Тел тидергесез** Һичбер гаеп ташларлык түгел; бик яхшы, әйбәт. *Практик сынауларны да тел тидергесез үткәннән соң, ГАИ начальнигы карт курсантны үзе котлаган.* А.Тимергалин. **Тел тидерү** 1) Гаеп ташлау, каршы сүз әйтү, шелтә белдерү. *Бигрәк тә шигырь турында сүз барганда, бигрәк тә татар шигыренә тел тидерә башласалар, Илдар абый ярсыган арысланга әйләнә торган иде.* Р.Миңнуллин; 2) Кемне дә булса яманлау, хурлау; тиргәү. *Андый хатынга тел тидерү – үзе зур гөнаһ ул!* Ф.Баттал. *Әнә бит Талгун бәккә берәүнең тел тидергәнен барып әйтүе генә булды, шундук йөзбашы итеп тә куйдылар, ә тел тидерүчене көньяк манарага күтәртеп астылар.* Р.Сәгъди. **Тел тимәслек** *к.* **тел тидергесез**. *Ханзафаров гомере буенча үзен тел тимәслек кеше итеп санап килде, кул астындагы кешеләрдән дә гел кадер-хөрмәт көнә күрде.* Г.Әпсәләмов. **Тел тотлыгу** *к.* **тел тотылу**. *Егет ташны күргәч, өнсез калды, теле тотлыкты: ташта егет комга язган тамгалар чекерәеп тора иде.* И.Хуҗин. **Тел тотылу** Сүзне әйтә алмый тору. *Сорадылар, җавап бирә алмадым, хәтерем адашкандай, телем тотылгандай кебек иде.* Ф.Яхин. **Тел төбе** Әйтелгән сүз артына яшерелгән теләк; сүзнең эчке мәгънәсе. *Шуңа да XXI гасыр укучысына, әлеге иҗатның нечкә серенә тулы мәгънәсендә ирешү өчен, шигъри сүз артына яшерелгән тел төбенә төшенергә кирәк.* А.Хәбибуллина. *Европа Русия белән дус яши, дисәләр дә, аларның тел төбендә башка мөнәсәбәт.* М.Басыйр. **Тел төбен тартып карау** Нәрсәдер турында кемнеңдер фикерен, аңа мөнәсәбәтен ачыкларга тырышу. *Тел төбен тартып кара, бәлки, риза булыр.* Т.Гыйззәт. **Тел туздыру** Бернинди мәгънәсе булмаган буш сүз сөйләү. *Сөйлиләр шунда тел туздырып, гомер уздырып.* Ә.Фәйзи. **Тел уйнату** Үзен күрсәтергә теләп, купшы сүзләр кулланып, оста итеп сөйләү. **Тел чайкау** *к.* **тел тидерү**. *Никләремә дип кенә шул фамилия белән тел чайкадым инде, ә?* Ф.Баттал. **Тел чарлану** Сүз сөйләргә остару, оста итеп сөйләргә өйрәнү. *Габделбәр элек алай түгел иде. Хәзер исә, ни хикмәттер, теле чарланган.* Ә.Фәйзи. **Тел чарлау** Кирәкмәгән сүз сөйләү, сөйләнү; кемгә булса да бәйләнү, аңардан көлү. *Минем сезнең белән тел чарлап торырга вакытым юк.* З.Зәйнуллин. *Урам буйлап үзеңне мактап, көндәшләреңне яманлап, үзең хакында уңай фикер тудырырга тырышып тел чарлап күп йөрергә була, әлбәттә.* Р.Хәкимов. **Тел чартлату** *к.* **тел шартлату**. --- *бабагыз тел чартлатып калды: «Әй-яй кәттә нәрсә бу!».* Ф.Баттал. **Тел чишелү** Дәшми торганнан соң сүзчәнләнеп китү, кинәт күп сөйли башлау. *Кәүсәриянең нишләптер теле чишелеп китте, гел сөйлисе килә, күңелне борчыган нәрсәләрнең һәммәсен дә сөйләп тышка чыгарасы, дөресрәге, менә шул ир белән уртаклашасы килә.* З.Мурсиев. *Тел чишелеп китүчән бит ул. Юктан гына уйларыңны ачып ташлавың бар.* Ф.Яхин. **Тел чишмәсе** Сүзгә осталык, матур сөйләү сәләте. *Башка вакытта да аның тел чишмәсе яман эшләми: сүз өчен кеше кесәсенә керә торган гадәте юк.* С.Поварисов. **Тел чишү** Сөйли башларга ярдәм итү яки мәҗбүр итү. **Тел чылату** Бераз исерткеч эчемлек эчү. --- *аның рюмкалары да нибары уймак хәтле генә, сыйдырган эчемлеге кече телне чылатырга гына.* Э.Касыймов. **Тел чылатырлык** Бик аз күләмдә. *Үзе таңдагы бер чык кына Кош телен чылатырлык.* Р.Бикбаев. **Тел шартлату** Тел белән шартлаулы тавыш чыгарып, аптырау, соклану яки ризасызлык белдерү. **Тел шомарту** Кызык өчен генә юкбар сүз сөйләү. *Фатыйх, гадәте буенча, бераз җиңеләеп маташты, ничек инде ул өч дус – өч яшьтәш – бергә очрашкач, табигать кочагында, фәләнтөгән дип тел шомарта башлаган иде – туктап калды.* М.Мәһдиев. **Тел юкарту** Сөйләү яки җырлау өчен, тавышны көйләү. *Уенга керешкәнче, һәммәсе дә тамак төпләрен ныгыта, телләрен юкарта.* Ф.Яхин. **Тел яздыру** 1) Хәйлә белән яки көч кулланып, кемнең дә булса серен алу, сөйләп бирергә мәҗбүр итү. *Гайния Хаҗиеваны нинди әмәл белән тел яздырырга?* Т.Әйди; 2) Нәрсәнең дә булса серенә төшенү, аны аңларга тырышу. *Хәлим, үҗәтләнә-үҗәтләнә, рус китапларын тел яздыра.* И.Гази. **Тел язу** 1) Берәр сәбәп белән күпмедер сөйли алмый торганнан соң ниһаять сөйләп китү, сөйләп бирү, сөйләшә башлау. *«Гаебе булмаса, тимәсләр иде», – диде аңа очраклы бер танышы. Ата да шуңа ышанды. «Арты юеш булмаса, тел язар иде!» – дип сыкранды...* А.Гыйләҗев; 2) Әйтмәскә тиешле сүзне әйтү, уйламыйча ялгыш сөйләп бирү; 3) Серенә, тәртибенә төшенергә, аңларга мөмкинлек ачу (җансыз-телсез нәрсәләр тур.). *Татарстанда девон юлының һәр борылышы таныш иде, ә монда каприз артыннан каприз. Кембрий һаман тел язарга җыенмый.* Ватаным Татарстан. **Тел язылу** *к.* **тел чишелү**. *Ничектер күңелләр ачылып китә, тел языла, сер чишелә.* З.Мурсиев. **Тел яшерү** 1) Хатын-кызның, бигрәк тә яшь киленнәрнең, ирләр алдында сөйләшми, дәшми йөрү йоласы. *Элек-электән безнең якта киленнәрнең кайнаталарыннан тел яшерү гадәте булган, ягъни киленнәр алар белән сөйләшмәгәннәр, дөресрәге, тегеләренә киленгә сүз катарга яраган,*

*ә киленгә – ярамаган.* М.Шәвәлиева; 2) Белгәнне әйтми калу, ачылып бетмәү. *Инде тел яшереп азаплануларның да әллә ни кирәге юктыр, Ходаем.* К.Тимбикова. *Табын тирәсендәге сөйләшүләр ничектер эчкерсезрәк була: бер-береңнән тел яшермисең.* Э.Халидов; 3) Башкалар аңламаслык итеп, белгертмәслек итеп, үзара кинаяләп, читләтеп сөйләү. *– Күптән шулай диләр аны, тел яшергән буласыз тагын, – диде ул Якубка, каш сикерткән булып. – Кемнән диген әле, иң якын дусларыннан бит.* В.Имамов

**ТЕ́Л АГЫ** *и.* Яшь балаларда авыз куышлыгын һәм тел өстен ак төскә кертә торган микроскопик гөмбә үрчеме белән характерлы авыру; *русчасы:* **молочница**

**ТЕЛӘГӘ́НЧӘ** *рәв.* Күпме теләсә, шул кадәр; ничек теләсә, шулай. *Профессорның китапханәсе бөтен Казанга атаклы иде. Ул яшьләргә аннан теләгәнчә файдаланырга рөхсәт итте.* Г.Әпсәләмов

**ТЕЛӘК** *и.* 1) Нәрсәне дә булса кирәксенү, теләү хисе; арзу. --- *шушы халәтнең мөмкин кадәр озагракка сузылуын теләде, ләкин теләк белән чынбарлык – икесе ике нәрсә шул.* В.Нуруллин

2) Кемнең дә булса эшенә, язмышына, киләчәгенә билгеле бер фикер, киңәш, мөнәсәбәт. *Карчык аңа да: «Явыз дошманны җиңеп, исән-сау килеш әтиәниең янына кайт», – дип теләк теләде, уң битеннән үпте.* Г.Әпсәләмов. *Үзең дә бәхетле бул! Миннән теләк шул!* Г.Гыйльманов. // Дога. --- *чишмәләргә халыкның мөнәсәбәте ничек? Алар янына теләк теләргә, корбан чалырга киләләрме?* Гали Рәхим

3) Ирешергә теләгән, алда торган бурыч, максат. *Үз гомеренең яртысы дип, ул кырык яшен билгели, шул яшькә кадәр кичергәннәр тәэсирлерәк, хыяллар байрак, теләкләр биегрәк була, күрәсең.* А.Гыйләҗев. *Һәм боларның барысы да бер теләк белән эшләнә: яшьләр авызыннан, минем Мөслимдә каласым килә, дигән сүзләрне ешрак ишетәсе иде.* Ф.Әхмәтҗанова

4) Ният, алдан корылган уй-план, фикер. *Яктылык арта барган саен, әле гарәп телен дә өйрәнергә теләк бар, Алла боерса.* Кәеф ничек?

5) Ихтыяр, ирек. *Әбүзәр Гиреевич, сезнеңчә ничек, минем теләк белән генә була торган эшме бу?* Г.Әпсәләмов. *Миңа әкиятне [кире] сөйләгәч, әкиятнең дәвамын тыңлыйсыңмы, әллә яңа әкият сөйләтәсеңме – ул синең теләк, мин аны үтим.* В.Ильясов

6) Үтенеч, гозер. *– Шулай алар берберсенә сөйләп, без яңа теләк белдерүчеләргә чыгабыз, брошюралар таратабыз, социаль челтәргә яңалыклар куябыз, – дип аңлатты ул.* Г.Гыймадиева

◊ **Теләккә килү** Җенси дәрт барлыкка килү, шәһвәт уяну (кеше, хайваннар тур.). *Хайваннар гына теләккә килә. Без – кешеләр – күңел, хис белән эш итәбез.* Факил Сафин. **Теләктә тору** Нәрсәнең дә булса үтәлүендә теләктәш булу, үтәлүенә теләктәшлек белдереп көтеп тору. *Хәзер мандат комиссиясенә барырга җыенабыз. Үтсәк, каядыр лейтенантлыкка укырга җибәрәселәр. Теләктә торыгыз инде...* Ш.Мостафин

**ТЕЛӘКӘ** *и.* 1) *этн.* Туку станогында кылычны күтәртеп куя торган тияк, чыгыр

2) *диал. к.* **калкавыч**. *Әнә, әнә чиртә, чиртә! Теләкәне тарта читкә, өстери төпкә!* Ш.Маннур

**ТЕЛӘКНАМӘ** *и.* 1) Әйбергә, тапшырылачак бүләккә аның иясенә атап теләкләр язылган язма, котлау язуы. *«Татарстан яшьләре» газетасына 80 яшь тулу уңаеннан укучылар арасында «Теләкнамә» дигән бәйге оештырылган.* Г.Сабирова

2) *этн.* Керәшеннәрдә котлау, теләкләр белдереп җырлана торган җыр жанры. --- *теләкнамәләр эчтәлек ягыннан тотрыклы һәм массовый түгел,* --- *теләкнамәләр күбесенчә гадәти булмаган конкрет хәлләр, язмышлар, көрәшләргә багышлана.* Н.Максимов

◊ **Теләкнамә әйтү** Теләкләр белдереп җырлау. *Теләкнамә әйтүнең билгеле бер ныклы калыбы бар, аның югары патетик дәрәҗәдәге ритмы, стиле, экспрессивлыгы бу жанрны форма ягыннан бик тотрыклы итә, теләкнамә әйтүче һәр кеше, бу жанрның формасын саклаган хәлдә, аңа үз фикерен, үз эчтәлеген, үз образын сала.* Н.Максимов

**ТЕЛӘКТӘШ** *и.* Кем белән дә булса уртак теләктә торган, бер үк нәрсәне теләгән кеше, фикердәш. *Аның шулай теләктәш булуы, күңелне җилкендереп торуы рәхәт иде, әлбәттә.* З.Зәйнуллин. *Мостафинның үзенә теләктәш булуы һәм ихлас сөйләшүләре, фикерләрнең туры килүе аны эчтән җылыта иде.* Х.Камалов

**ТЕЛӘКТӘШЛЕК** *и.* 1) Теләктәш булу; кемнең дә булса теләген куәтләү, яклау, хуплау. *Бу сүзләрнең кызда да ихлас теләктәшлек тудыруына ул чиксез нык ышана.* А.Вергазов. *Өстәвенә килендәшен бик тә үз итә, аңа һәрчак теләктәшлек күрсәтә.* М.Маликова

2) Фикердәшлек, уртак мәнфәгатьтә булу. *Син нишләп миңа, үз иреңә, теләктәшлек белдерәсе урынга, мине көрәшемнән баш тартырга өндисең?!* З.Хәким. *Читтән үзләренең бу хәрәкәтләренә ниндидер реаль теләктәшлек, ярдәм булмаячагы ачык сиземләнә.* М.Гайнетдинов

**ТЕЛӘКЧЕ** *и. к.* **догачы**. *Үзең үлгәч, теләкчең калсын.* Әйтем

**ТЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Теләнергә мәҗбүр итү. *Сабый чагында аны нэпманнар бер телем ипигә тилмертеп теләнче итте, егет чагында сугышта солдат намусына дегет ягылгач, немец фермерлары теләндерде.* Ш.Рәкыйпов

**ТЕЛӘНЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **теләнү**. *Мөндәриҗәнең сыеклыгы, күбесенчә бер үк әйберне кырык төрле итеп тәкрар кылу белән тутырырга теләнелгән төсле тоела.* Гали Рәхим. *Басуларда иң еш теләнелә торган теләк бу.* Кызыл таң

**ТЕЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **теләү** I. *Йолдыз атылганда теләнгән теләк тормышка аша, аны Тәңре ишетә, диләр бит.* Г.Гыйльманов

2) Садака сорап йөрү, сорану, хәер эстәү. *Теләнү хәерчеләргә хас.* Т.Миңнуллин

3) *куч.* Үзенә кирәк һәрнәрсәне сорапып алу, зарланып, кызгандырып табу. *Яковтан әҗәт теләнгән шикелле кыюсыз гына сорап юлга чыкты Әмир.* В.Имамов. *Тегендә, иректә, аның ту-*

*ганнары юк шикелле, посылка-фәлән алганы юк аның, хат та язмыйлар, кемгә ярый ала, шуңа хезмәтче булып, тәмәке, чәй теләнә.* К.Кара

**Теләнә башлау** Теләнергә тотыну. *Шагыйрьләр кызлар вә хатыннардан мәхәббәт теләнә башладылар.* Т.Миңнуллин. *Берәр нәрсә теләнә башласа, котылам димә!* М.Маликова

**Теләнеп йөрү** Шактый вакыт яки һәрвакыт теләнү

**ТЕЛӘНҮЧӘН** *с.* Еш теләнә торган булып, теләнү гадәте алып, соранучан. *Ахыр килеп, җыен иске-москыдан йөри башлады, барактагылардан «бер чокырлык кына» теләнүчән булып китте.* Ш.Маннур

**ТЕЛӘНЧЕ** *и.* Теләнеп, соранып көн күрүче кеше, хәер эстәүче, хәерче, саил. *Мәчет капкасы төбендә берничә теләнче хәер көтеп утыра.* Р.Батулла. *Салымчы киткәч, янымда басып торган теләнче карт миңа сүз катты.* М.Сәлим

◊ **Теләнчегә бер тамчы** Теләнеп алган әйберенә куану, канәгатьлек белдерү сүзе. **Теләнчегә теллә** (**хәерчегә хөллә**) **бирү** Тиешсезгә артык кадер-хөрмәт күрсәтү, артык юмартлану

**ТЕЛӘНЧЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бөтен кирәген теләнче кебек соранып алу, теләнеп булдыру; үтечкә еш сорап йөдәтү

2) *к.* **теләнү** (*2, 3 мәгъ.*). *Юк ирде бу кызның һәм анасы, Теләнчеләп бер өйгә килде.* Мөхәммәдьяр

**Теләнчеләп йөрү** Гел, һәрвакыт, әледән-әле теләнчеләү. *Шәһәр урамына чыгып теләнчеләп йөр, алкаш улыңны ачтан үтермим дип тырышкан бул.* М.Кәбиров

**ТЕЛӘНЧЕЛЕК** *и.* 1) Теләнче булу; теләнче хәле. *Үзе сукыр иде, өй буенча йөреп, теләнчелек берлә ризыкланыр иде.* К.Насыйри. *Әптелбәр инде үзенең теләнчелеген берәүдән дә яшерми, ачыктан-ачык соранып йөри башлады.* Ә.Фәйзи

2) *куч.* Ялынып-ялварып, бертуктаусыз зарланып, соранып туйдырып бетерү, теңкәгә тию гадәте. *Фикер, идея теләнчелегенә яки беркемгә кирәксез арзанлы фикерләргә мисал итеп, шул ук Теләшнең «Большевиклар язы», «Таң яна» һәм башка бик күп шигырьләрен алырга мөмкин.* Һ.Такташ. – *Нәрсә бирим, дигән буласың, беләсең ич инде язу кирәген, – диде Шмит, кызганыч елмаю белән. – Син ул теләнчелегеңне ташла, егет, – диде Ифрат.* А.Расих

**ТЕЛӘНЧЕЛЕ́К ИТҮ** *ф. к.* **теләнү**. *Анда фәкыйрь юк, ач-ялангач, теләнчелек иткән зәгыйфь юк, актык сулышында авызына су салырга кешесе булмаган авыру юк, золым юк, җәбер юк – һәр җирдә тигезлек, һәр җирдә гадаләт.* Г.Исхакый. *Бу инде Ходай биргән көчеңә таянып түгел, намусың, абруең сатып, алдашып яки ялагайланып, теләнчелек итеп тапкан ризыгың.* Л.Хәмидуллин

**ТЕЛӘ́Р-ТЕЛӘМӘС** *рәв.* Бик үк теләмичә, таләпкә буйсынып кына. *Башкалар теләр-теләмәс кенә алар артыннан иярделәр.* Н.Фәттах. *Рухия үпкәләде. Кайтырга кузгалгач, рюкзагын да Равилгә теләр-теләмәсрәк кенә бирде.* В.Нуруллин

**ТЕЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **теләү** I

2) *этн.* Мәҗүси дога кылдыру. *Теләвен теләткән, келәтен бураткан.* (туйга әзерлек тур.) Әйтем

**ТЕЛӘ́Ү** I *ф.* **1.** 1) Нәрсәне булса да кирәк санау, арзу итү; теләк барлыкка килү. *Җир әйтерсең шул тимер бурны үзе теләп йота.* А.Алиш. *Безнең авылдан үзләре теләп сугышка ике япьяшь кыз – Нәҗия һәм Сабира апалар китәләр.* Яңарыш

2) Теләк сүзләре әйтү. *Кызын да кешеләргә ышану, гел изгелек теләү, яхшылык эшләү рухында тәрбияләде.* Т.Галиуллин. *Шәкертләр, нәүрүз такмагын укып яки яттан әйтеп, йорт хуҗаларына бәхет һәм уңыш теләп йөргәннәр.* А.Тимергалин

3) Берәр нәрсә ашыйсы килү теләге уяну. *Бу төргәкне ул Габделхәйгә чыгып бераз яшәгәннән соң, тозлы кыяр тели башлаган кебек сизгәч, яшереп кенә район кибетеннән алып кайткан иде.* Г.Бәширов

4) *этн.* Мәҗүси гыйбадәт кылу, мәҗүси илаһка ялвару. *[Кеше] Күрә-күрә күрәзә булыр, тели-тели телмәрче булыр.* Мәкаль. *Тиябирсен итү, тәберсен итү – керәшеннәрдә, ашарга утырыр алдыннан, вафатларны да табынга чакыру һәм аларга ахирәттә һәртөрле рәхәтлекләр теләү догасы, ул күңелдән генә укыла.* А.Тимергалин

**2. теләсә** *а. мәгъ.* Сорау алмашлыклары белән берлектә «һәр», «һәрбер» мәгънәсендә килә. *Беренче стадиядә алар теләсә кемгә яки теләсә нәрсәгә – ир кешегә, хатын-кызга, акчага, балаларга, җиргә яки ташларга табыналар.* А.Тимергалин. --- *вакыт-вакыт тел очын гына чыгарып, күперенке ирен читләрен ялмап алулары да теләсә кайсы ир затын акылдан яздырырлык иде.* А.Әхмәтгалиева

**Теләп тору** Гел, даими теләү; әле, хәзерге вакытта теләү. *Барысы да әйбәт булыр, теләп тор, бөтен нәрсә Ходай кулында, нишлисең бит...* Г.Гыйльманов

**Тели башлау** Теләргә тотыну. *Бервакыт шуның [Ходайдатның] хатыны, балага авырып, җирдән хәзер генә өзеп алынган яңа җир җиләге тели башлаган.* Г.Ибраһимов

**Тели төшү** Тагын да теләү

**ТЕЛӘ́Ү** II *и. к.* **теләк** (*1 мәгъ.*). *Кеше, әгәр бик нык теләсә, әллә ниләр башкара ала. Күп чакта теләү җитми адәм баласына.* А.Гыйләҗев

**ТЕЛӘ́Ү** III *и. этн. к.* **келәү**. *Шул җанкай белән кавышсам, корбан суяр идем теләүгә.* Җыр

**ТЕЛӘҮЛЕК** *и. этн.* 1) Борынгы төрки мәҗүсилектә пот, санәм. *Теләүлеккә тәрәүлек (кирәкмәгән эшкә ярдәм).* Әйтем. *Авыл читендәге теләүлек дип аталган агачларга карап табыну аларның [авыл кешеләренең] гадәте булган. Бу теләүлекнең берсе әле дә Түнтәр авылының басу кырында шулай дип саклана.* Р.Зарипов

2) Мәҗүси корбанлык, корбан ителә торган әйбер, чалына торган терлек

◊ **Теләүлек шикелле кату** *к.* **теләүлек шикелле тору**. **Теләүлек шикелле тору** Селкенми, кымшанмыйча торaташтай тик тору. *Ник терәлеп каттың теләүлек шикелле?* Ш.Маннур

**ТЕЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **теләү** I. *Кырык тугызынчы елның октябрь азакларында әнә шундый матур-матур теләкләр теләшкән иде алар.* В.Нуруллин

2) *этн.* Теләүдә (III) катнашу. *Карга теләгеен теләшкән тартай үзенә давыл китергән.* Мәкаль

**ТЕЛБИЗӘК** *и.* Сүз сәнгатендә төрле тәгъбирләр һәм тасвирлау чаралары системасы. *Еллар үткән саен, яңа бер әсәрне иҗат иткән саен, язучы тормыш материалларына тирәнрәк үтеп керә, телбизәкләргә таләпчәнрәк, төгәлрәк була бара.* И.Гыйләҗев

**ТЕЛБИСТӘЛЕК** *и.* Күп сөйләү гадәте. *Ул сорау сүз югыннан сүз булсын өчен генә бирелгән мәгънәсез бер телбистәлек күрсәтү төсле тоелды.* Ш.Камал

**ТЕ́ЛБИСТӘСЕ** *с.* Артык күп сүз сөйләүчән. *Палатадагы бөтен авырулар да тынга калды, телбистәсе умартачы карт та беравык тын торды.* Р.Кәрами

**ТЕЛГӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **телгәләү**. *Аннан соң, акылына килеп, койрыкны яшерер өчен, телгәләнеп ыргытылган дәфтәр кисәкләрен җыеп алды да аларга ут төртте.* С.Поварисов

2) Бик нык искереп тузу, сәләмәләнү. *[Карт] Ел әйләнәсе диярлек бер пальтода йөри, --- эче тәмам телгәләнеп, җиң очлары, чабулары кыршылып, зур төймәләре яртылаш сынып беткән.* Ә.Еники

3) Теленү, ерткалану. *Киемнәре, телгәләнеп, чиләнеп, кан-туфрак белән укмашып, җирдә ята.* Р.Батулла. *Җилгә каршы бару җиңел түгел, Телгәләнә җилдә җилкәннәр.* Г.Гайнетдинова

4) Ергалану. *Биредә тигез дала тәбәнәк калкулыклар, инешсез коры үзәнярлар белән телгәләнә.* Х.Камалов. *Аларның яфраклары эре, ике тапкыр каурыйсыман телгәләнгән.* Л.Мәүлетова

5) Кискәләнү, яргалану. *Һәр гөнаһ кылган гунн --- үзенә үзе җәза бирә икән: --- битенә бер тапкыр пычак белән сыза, ике булса – ике, өч булса – өч. «Шуның өчен гуннар арасында тәмам битләре телгәләнгән кешеләрне дә очратырга була», – диде Максимин.* М.Хәбибуллин. *Ярга сыймый, телгәләнеп ярыла Минем йөрәк кебек бу бозлар.* Ф.Җамалетдинова

6) *күч.* *Йөрәк, бәгырь* һ.б.ш. сүзләр белән килеп, «бик нык әрнү, өзгәләнү, газаплану» дигәнне белдерә. *Күргән саен йөрәге телгәләнә, шул сөйкемле әбигә ярдәм итәсе килә.* Р.Җиһаншина. *Укытучының да күзләре чыланды, малай өчен бәгыре телгәләнә иде.* З.Мурсиев

**Телгәләнә бару** Торган саен ныграк телгәләнү

**Телгәләнә башлау** Телгәләнергә тотыну. *Тәүлеккә якын тәгам ризык күрмәгән өч кечкенә балага карап, Кавиның йөрәге телгәләнә башлады.* З.Зәйнуллин

**Телгәләнеп бетү** Тәмам, бик нык телгәләнү. *[Сугышчыларның] Өсбашлары телгәләнеп бетте.* Г.Бәширов. *Газеталар укыла-укыла телгәләнеп бетәләр.* А.Гыйләҗев

**Телгәләнеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыйгадан соң телгәләнү. *Вакытлар узу белән, чыршы тәнендәге җәрәхәтләр төзәлә. Буй-буй телгәләнеп калган яфраклар да, ныгып, үткен энәне хәтерләтә башлый.* Г.Гыйльманов

**Телгәләнеп китү** Кинәт телгәләнү. *Әмма шулчак нәфрәт тулы күз карашыңнан йөрәгемнең телгәләнеп киткәнен гомеремдә дә онытасым юк.* Г.Галиева. *Шул чакларда Габделбәрнең бәгыре телгәләнеп китә: аны үтмәс пычак белән сызып җибәрәләр.* Ә.Сафиуллин

**Телгәләнеп чыгу** Тәмам теткәләнеп телгәләнү. *Арка тиресе суелып, телгәләнеп чыкканчы камчы сукканнар – эндәшмәгән, өстенә менеп таптаганнар – эндәшмәгән ---.* Э.Касыймов

**ТЕЛГӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бик күп тар, юка кисәкләргә телү, кисү, яру. *Маһруй, өстенә кигән ике итәкле күлмәген салып, шул күлмәкнең бер итәген ертып алып һәм телгәләп, бау-аркан үрергә тотынды.* З.Бигиев

2) *күч.* Газаплау, борчу, әрнетү. *Үзәген телгәләп, тагы улы күз алдына килде, намаз вакытында бераз онытылып торган борчулы уйлары тагы башына ябырылды.* Ф.Бәйрәмова

**Телгәләп алу** Кинәт, аз гына вакыт телгәләү. *Әгәр бу балалар, бая Газзәбану әйткәнчә, бездән китә калсалар, үзләре белән тормышыбызның бөтен ямен алып китәчәкләр бит. Яшәвебезнең бер мәгънәсе дә, бер кызыгы да калмаячак, диган уй Зарифның йөрәген телгәләп алды.* Г.Галиева

**Телгәләп бетерү** Тәмам, бик нык телгәләү. *Ашкынып туган якка кайту һәм, ни кызганыч, тагын ун елга төрмәгә элэгү... – һәммәсе дә Бал бабайның йөрәген телгәләп бетергән иде.* Л.Шәех

**Телгәләп кую** Алдан телгәләү; кинәт бер мәртәбә яки берара телгәләү. *Камәрия абыстай эчке күлмәгенең итәген ертып алды да чүпрәкләргә телгәләп куйды – баланың астын алмаштырырга.* И.Сираҗи. *--- бу кадерле кешенең юклыгы үзен сиздереп, йөрәкне бераз телгәләп куя.* Равил Вәлиев

**Телгәләп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз телгәләү; әле, хәзерге вакытта телгәләү. *Әмма Мазлуманың моңлы тавышы белән: «Бармыйм, авылыма кайтам», – дип инәлүе һаман колак төбендә яңгырап, йөрәкне телгәләп тора.* Г.Бәширов

**Телгәләп чыгу** Һәрберсен, булган берсен башыннан ахырына кадәр телгәләү. *[Кышның зәһәр салкыннарында да яфрак коймыйча, ямь-яшел килеш утыру өчен] Чыршы, каты авыртуларга түзә-түзә, калган яфракларын да буй-буй тасмаларга телгәләп чыккан.* Г.Гыйльманов

**Телгәли бару** Торган саен ныграк телгәләү; булган берсен рәттән телгәләү

**Телгәли башлау** Телгәләргә тотыну. *Җир өстеннән күккә юнәлгән прожектор утлары, яктылык кайчылары булып, караңгылыкны телгәли башлады.* Ф.Хуҗин

**Телгәли төшү** Тагын да телгәләү; бераз гына телгәләү

**ТЕЛГӘЧ** *и. иск.* Үзенең мөстәкыйль фикере булмаган, чит кеше фикерен куәтләүче, башкалар сүзен сөйләүче кеше. *[Ялагайның] Күзе – көзге, теле – телгәч.* Мәкаль

**ТЕЛГЕЧ** *и.* **1.** Чыра, каеш һ.б.ш.ны телү өчен махсус пычак, пәке

**2.** *с. мәгъ.* Телә торган, телү өчен хезмәт иткән. *Каһир --- фонарьны чайпалдырып, керосины җитәрлеген барлагач, филтә күмерен чыра телгеч пычак белән кырып үтте.* Ә.Гаффар

**ТЕЛДӘН** *рәв.* Язмача түгел, әйтеп, сөйләп. *Шаман өстеннән жалобалар*

*күп. Язылганы да, телдән әйтелгәне дә байтак.* А.Гыйләҗев. *Татарча һәм русча язма һәм телдән, шуның өстенә тарих, география ---.* Ә.Рәшит

**ТЕЛДӘР** *с.* 1) Күп сөйли торган, сүзчән, сөйләмчәк. *Болары Маратка бик кызык булмаса да, ул телдәр абзыйны бүлдерми генә тыңлап утырды.* Д.Гыйсметдин. *Чандыр гына, телдәр экскурсовод кызыкай горурлык катыш мавыгу белән легенда сөйләвендә.* Д.Булатова

2) Телчән, телләшергә оста; үткен, чая телле. *Тәслимә шул чая кызларның берсе иде. Ай-һай, телдәр кызлар булдылар болар!* Ф.Абдуллин

**ТЕЛДӘРЛӘНҮ** *ф.* Телдәр булып китү; артык оста сөйли башлау. *Эш ул телдәрләнүне яратмый, эшләгәнне ярата.* Х.Камалов

**Телдәрләнә бару** Торган саен ныграк телдәрләнү

**Телдәрләнә башлау** Телдәрләнергә тотыну

**Телдәрләнә бирү** Һаман телдәрләнү, телдәрлеген дәвам итү. *Самат телдәрләнә бирде: – Һөнәрегез буенча врач инде сез. Эшләвегез Казанда.* Б.Камалов

**Телдәрләнә төшү** Тагын да телдәрләнү

**Телдәрләнеп бетү** Тәмам, бик нык телдәрләнү

**Телдәрләнеп китү** Кинәт яки торабара әкренләп телдәрләнү. *Зөбәрҗәт бөтенләй телдәрләнеп китте. Ул инде Саниягә авыз ачарга да бирми сөйләнә иде.* М.Әмир. *Мәгъдәни кинәт туктады һәм, телдәрләнеп китеп артык нәрсә ычкындырмадыммы дигәндәй, Данияр белән Сәет ягына сораулы караш ташлап алды.* М.Хәсәнов

**ТЕЛДӘРЛЕК** *и.* Телдәр булу сыйфаты. *[Бу мәкаль] Ят кешеләр алдында ата-анадан узып, үзләре телдәрлек иткән тәрбиясез балалар хакында.* Н.Исәнбәт

**ТЕ́ЛЕ-** I *гр.* Кушма сүзләрдә «телевидениегә бәйләнеше булган, телевидениегә мөнәсәбәтле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *телеспектакль, телестудия*)

**ТЕ́ЛЕ-** II *гр.* Кушма сүзләрдә «техник җайланмалар ярдәмендә ерактан идарә итүгә (элемтә тотуга) карый торган» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *телемеханика, телесигнализация*)

**ТЕЛЕВИ́ДЕНИЕ** *и. гр.-лат.* 1) Электр һәм радиоэлемтә чаралары ярдәмендә хәрәкәттәге яки хәрәкәтсез булган объектларның сурәтләрен ерак араларга җибәрү һәм кабул итү ысулы. *Ул – Молдованың авыл җирендәге классларына телевидение техникасы монтажланган икенче мәктәбе.* Т.Әйди

2) Телевизион программалар төшерү һәм тарату белән шөгыльләнгән оешма. *Бакый Урманченың шушы әсәрен [«Сагыш» скульптурасын] үзәккә куеп төшерелгән, «Сагыш» дип исемләнгән документаль фильм бүген телевидениенең алтын фондында саклана.* Мәдәни җомга

3) Массакүләм мәгълүмат чараларының күңел ачу, тәрбия-белем бирү, реклама һ.б.ш. функцияләрне башкарган бер төре. *Бу концертны телевидение турыдан-туры күрсәтеп торган икән.* Д.Гыйсметдин

**ТЕЛЕВИЗИОН** *с.* 1) Телевидениегә мөнәсәбәтле; телевидение өчен кирәкле. *Автомат металл чыңы кебек зәһәр, ясалма бер тавыш белән беренче сүзләрен әйтте: – Миңа хәрәкәтчел ике телевизион көпшә, ягъни күзләр кирәк.* А.Тимергалин

2) Телевидение аркылы җибәрелә, күрсәтелә торган. *Тукай ролен ул [Илдус Әхмәтҗанов] беренче тапкыр 1976 елда режиссёр Әхтәм Зарипов куелышындагы «Яз сулышы» исемле телевизион спектакльдә башкара.* Г.Бәйрәмова. *Ә берзаман, моннан ун еллап элек, телевизион марафон да оештырдылар, акча да җыйдылар, һәйкәл куябыз Сәйдәшкә дип.* Р.Вәлиев

**ТЕЛЕВИ́ЗОР** *и. гр.-лат.* 1) Телевизион аппарат; телевидение аша җибәрелгән сурәтләрне шуларга караган сүзләр, авазлар белән бергә кабул итә һәм күрсәтә торган радиотехник җайланма. *Тормышыннан зарланмый, тик менә пенсиясе генә кечкенә икән, яхшы телевизор сатып алып булмый, ди.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Телевидение. *Чигүле түбәтәй, яшел атлас камзул, эленке генә бәйләнгән, туры төпле, озын балаклы буй-буй ыштан киеп биегәнен телевизордан еш күрсәтәләр.* К.Кәримов

**ТЕЛЕГРАМ** *и. фр. сөйл.* 1) *к.* **телеграмма**. *Сафуанов абый андамы? Аңа телеграм бар, телеграм!* А.Тимергалин

2) Телеграф линиясе. *Олы юлкайларда телеграм Мәскәүләрдән барадыр Казанга.* Җыр. *Телеграм баганаларын саный-саный, һаман саен ераклыкны арттыра барды.* В.Имамов

◊ **Телеграм баганасы** Озын буйлы кеше. *Кәрим Җаманаклы (үз фамилиясе Рәшидов) гаҗәеп бер пәһлеван зат иде. Үзем кыска буйлы булгангадыр инде, «телеграмм баганасы»на кызыгып карый идем.* Г.Гомәр

**ТЕЛЕГРА́ММА** *и. фр.* Телеграф аша җибәрелгән хәбәр. *--- тагын бер кат телеграмманы укып чыкты, адресын карады, кайсы шәһәрдән, кайсы вакытта бирелүен тикшерде.* А.Гыйләҗев

◊ **Телеграмма бирү** *к.* **телеграмма сугу**. *Ничек тә әнисе янына кайтып җитәргә иде бит. Әтисе юкка гына телеграмма бирмәгән инде ул.* Д.Бүләков. **Телеграмма сугу** Телеграф аркылы хәбәр җибәрү. *Доктор Шәфкатия Ширәмәттән Казанга иң беренче рейска ук урын калдыруларын сорап телеграмма сукты.* А.Тимергалин

**ТЕЛЕГРАФ** *и. ингл.* 1) Ерак арада хәбәрләшү өчен үткәргеч чыбыклар, техник җайланмалар системасы. *«Сәламәтлегем шәп түгел, врачлар шулай куша», – диган булып, җәй саен диңгез буена ялга йөри, анда алып киткән акчасын туздырып бетерә дә, кайтыр юлга акчам калмады дип, телеграф аша сорап алдыра иде.* В.Нуруллин

2) Шуңа караган бина, пункт. *--- ул телеграфка кермичә, бөрешә төшкәндәйрәк итеп, алга атлады.* Р.Мирхәйдәров

**ТЕЛЕГРАФИСТ** *и. рус к.* **телеграфчы**. *Өйрәнүләр вакытында элемтә белән эш итәрсез: радист, телеграфист булырсыз.* Җ.Дәрзаман

**ТЕЛЕГРАФИ́СТКА** *и. рус* Телеграфчы хатын-кыз. *Казан шәһәрендә махсус курсларда укып телеграфистка һөнәре ала һәм район элемтә бүлегендә*

*шушы һөнәре буенча хезмәт юлын башлый.* Г.Мөхәммәтшин

**ТЕЛЕГРАФИ́Я** *и. гр.* Телеграф элемтәсе эше; аның төзелеш принципларын, сигналларны ераклыкка тапшыру ысулларын, техник җиһазларын өйрәнә торган фән-техника тармагы

**ТЕЛЕГРАФЧЫ** *и.* Телеграф аппаратында эшләүче, аппарат төзелешен һәм Морзе билгеләрен белгән кеше. *Казанда яшәүче Антонина Заикина да сугышның башыннан ахырына кадәр фронтта телеграфчы булып эшли.* Н.Алан

**ТЕЛЕКОМБАЙН** *и. рус иск.* Телевизор белән радиоалгычны берләштергән аппарат. *Бер читтә телекомбайн, икенче почмакта озын аяклы «Ригонда» радиоалгычы [тора].* Б.Камалов

**ТЕЛЕМ** *и.* Бөтеннән телеп алынган өлеш, юка итеп кисеп алынган яссы кисәк. *Берьялгызы гына байтак казырга туры киләчәген чамалап, ашарга, май ягып, ике телем ипи һәм шешә тутырып су алды.* А.Тимергалин. *Каен ярканың башыннан телем итеп кисеп алынган алканы тал ботагыннан ясалган кәшәкәләр белән ярылганчы кыйнадык.* В.Нуриев

**ТЕЛЕМЕ́ТРИК** *и.* 1) Телеметриягә бәйләнешле. *Дәрәҗәле инженерлар белән беррәттән безгә телеметрик элемтә системасын эшләү вазифасы йөкләнде.* Р.Юсупова

2) Телеметрия ысулы белән алынган. *Станциядән телеметрик мәгълүмат алу*

**ТЕЛЕМЕТРИ́Я** *и. гр. тех.* 1) Нинди дә булса аппаратлар, машиналар белән ерактан торып элемтә тоту, аларга бирем, боерык тапшырып, мәгълүмат кабул итү эше

2) Шул эшкә караган техник чаралар системасы

**ТЕЛЕМЕХА́НИК** I *и. рус махс.* Телемеханика белгече

**ТЕЛЕМЕХА́НИК** II *с. махс.* Телемеханикага караган. *Нефтьчеләр инде элекке сыман һәр юк-бар өчен дә телләрен салындырып чабып йөрмиләр, телемеханик система һәр хәвефле хәлне промысел диспетчерына җиткереп тора.* Җ.Рәхимов

**ТЕЛЕМЕХА́НИКА** *и. рус махс.* 1) Төрле аппаратлар, машиналар һәм җайланмалар белән ерактан торып идарә итү эше

2) Ерактан торып идарә итү системасы һәм шуңа караган барлык техник чаралар. *Мине бит монда командировкага телемеханика системасын, электрон хисаплау җайланмаларын корырга дип җибәрделәр.* Ш.Бикчурин

3) Шул системалар турындагы фән. *Әйтик, бу – физика түгәрәгенең автоматика һәм телемеханика мәсьәләләренә караган бер өлеше булсын, ди.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Курамшин иртәдән алып кичкә кадәр Черек күлдә, ә эштән кайткач, яшьләргә электроника һәм телемеханика серләрен өйрәтергә китә.* Ш.Бикчурин

**ТЕЛЕМЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **телемләү**. *Өченче кат зефир һәм каймак өстенә телемләнгән бакча җиләген җәябез.* Сөембикә

**ТЕЛЕМЛӘП** *рәв.* Телемнәр рәвешендә; телемнәргә бүлгәләп; телемнәр белән санап. *Улай дәдә, күкрәгенә терәп, тегермән ташыдай икмәкне телемләп турый башлады.* Р.Батулла

**ТЕЛЕМЛӘ́Ү** *ф.* Телү; телемнәргә кискәләү. *Әмир хәзрәтләре аны, үз кулы белән телемләп, дәрвишләргә өләшкән, үзенә хәтта авыз итәргә дә калдырмаган.* Т.Әйди

**Телемләп кую** Алдан телемләү; телемләнгән хәлгә китерү. *Иртән коймагын пешереп өлгертә, чәен өстәлгә бирә, ялт иттереп, мул күкрәгенә терәп, ипиен телемләп куя.* Т.Галиуллин

**Телемләп ташлау** Тиз-тиз телемләү. *Килеп керү белән, чөйдә эленеп торган ашъяулыкны алып, аны сәкегә җәеп, Хәсәнә абыстай әлеге кабарып пешкән зур бодай икмәген телемләп ташлады.* С.Поварисов

**Телемләп тору** Әле, хәзерге вакытта телемләү; туктаусыз телемләү

**Телемләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да телемләү

**Телемли бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы телемләү

**Телемли башлау** Телемләргә керешү

**ТЕЛЕМЛЕ** *с.* 1) Телемнәрдән торган, теленеп куелган. --- *узган елда киптерелгән телемле алма кисәкләрен кайнаган суга салып ачыта.* М.Мәһдиев

2) Теленеп торган, телгәләнгән. *Түгәрәк, бармаксыман телемле яфраклары бераз металл ялтыравыклы һәм алмаш торышлылар.* Ф.Закиров

**ТЕЛЕ́М-ТЕЛЕМ** *рәв.* **1.** 1) Кисәк-кисәк телеп, күпкә бүлгәләп. *Әни телем-телем кара икмәк кисә.* Р.Зарипов. *Телем-телем турасаң да, мин улымны сатмыйм.* В.Имамов

2) Бер-бер артлы телемләп; бер телем артыннан икенче телем итеп. *Тоз сипкән икмәкне телем-телем бөгәсең.* Г.Ибраһимов. *Савытыннан бөтен килеш төшкән балык консервасы янында телем-телем ак серкәле редис тәгәрәшеп ята.* К.Кәримов

3) Тасма-тасма, буй-буй итеп. *Телем-телем телгәләнгән күлмәк итәкләре шуңа күрә җәһәтрәк җилфердиләр.* А.Гыйләҗев. *Ак йөзләре телем-телем булып теленгән.* Н.Гамбәр

4) *күч. Йөрәк, күңел, бәгырь* кебек сүзләр белән берлектә «бик нык газап чигеп, әрнетеп, ачындырып» мәгънәсен бирә. *Ник егетнең яшь йөрәген Телем-телем кисәсең?* М.Җәлил. *Телем-телем бәгырь өзелә!* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* Телемнәргә бүленгән. *Үлән арасында вак-вак, телем-телем ука чуклы сары чәчәкләр.* Г.Сабитов

**ТЕЛЕНМӘ** *с. к.* **теленмәле**. *Овал сыман чит-чите теленмә яфрак*

**ТЕЛЕНМӘЛЕ** *с.* Кырыйлары телгәләнгән, чит-чите телле-телле булган. *Олы яфракларның төзелешенә игътибар итегез: аның җәймәсе ике тапкыр каурый сыман теленмәле, ә читләре шома.* Л.Мәүлетова

**ТЕЛЕНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **телү**. *Телем-телем телендем Мин искергән җиләндәй.* Дәрдеменд

2) Ерткалану, бүлгәләнү, телгәләнү. *Елан аеры теле белән бары тик аның [карлыгачның] койрык очын гына эләктерә алган, ул да булса, теленеп, елан авызында торып калган.* Әкият

3) *күч.* Яргалану, кискәләнү. *Ул бозга янә балта очы белән сукты, бәке кыреендагы үткен, үтәкүренмәле уалган пыяладай кисәкчекләр теленеп, чупылдап суга чумды.* Ф.Җамалетдинова

4) *күч. к.* **телгәләнү** (*6 мәгъ.*). *Шәмсүн аркасында Гөлфинур белән сүзгә*

*килгән көнне ничек авыр булган иде аңа, бәгыре парә-парә теленгән иде.* А.Вергазов

**Теленеп бетү** Ахырга кадәр, беткәнче теленү; тәмам, бик нык теленү. *Аркылы такталарының байтагы чыралыкка теленеп беткән сәкеләрдә барабызчылар утыралар.* К.Нәҗми. *Аның күңеле борчылу, курку, әсәрләнүдән теленеп беткән.* Г.Әпсәләмов

**Теленеп китү** Кинәт теленү. *Тавышыннан җаннар теленеп китеп, күзләремне минем томан кымде...* Ф.Яхин

**Теленеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тоташ теленү. *Карасу бәк сөңге тотып каршы төшкән иде, әмма берничә мизгелдән соң ул инде, тоташ теленеп чыккан бугазы белән гырылдап, аяк астына ауды.* В.Имамов

**ТЕЛЕПАТ** *и. гр.* Телепатия куәсенә ия булган кеше. *Вашингтонда хайваннарның уйларын укучы телепат атын югалткан хатынга малның ниндидер тыгыз, куаклы, сулы урынга төшүен әйткән, һәм хайванны, чыннан да, чокырдан табып алганнар.* Татарстан яшьләре

**ТЕЛЕПА́ТИК** *с.* Телепатиягә мөнәсәбәтле. *Бик ерактан киләләр, барасы юллары озын, шуңа аларга үзләренең сүлпәнләнә төшкән телепатик сәләтләрен уятып җибәрү зарур.* Р.Фәизов

**ТЕЛЕПА́ТИЯ** *и. гр.* Кеше үз уен, фикерен ераклыкка тапшыра алу яки ерактан торып башка берәүнең фикерен кабул итү белән характерлы гайре табигый сәләт. *Телефон аша да мин сезне күреп торам. Телепатия бик көчле минем.* Т.Миңнуллин. *Һәркемдә күпмедер дәрәҗәдә телепатия була, диләр, дөрес, ахры.* Г.Гомәров

**ТЕЛЕСКОП** *и. гр.* Галәмне, галәм киңлекләрендәге җисемнәрне күзәтү өчен астрономик оптик әсбап, җайланма. *Телескоптан Юпитерның иярченнәрен дә күргәнем бар...* А.Тимергалин. *Ә беркөнне хатын сандык төбеннән улына әтисенең истәлеге булып калган телескопны алып бирә.* Г.Гомәров

**ТЕЛЕСКО́ПИК** *с.* 1) Шудырма җайланмалар белән озынайтыла торган; телескопка охшаган, телескоп принцибында эшли торган. *Зур өйдәге үз бүлмәсендә компьютеры, --- телескопик саплы бик яхшы кармаклары, ботинкалы тимераягы, пластиктан ясалган, күз явын алырлык чаңгылары.* Р.Фәизов. *Барлык эшче органнарга хәрәкәт бирү механизмнары ургычның уң ягында урнашкан, һәм телескопик карданлы вал ярдәмендә хәрәкәтне комбайнның төп контрприводыннан алалар.* Урып җыю машиналары

2) Телескоп аркылы гына күренә торган. *Телескопик планеталар*

3) Телескоп ярдәмендә башкарылган. *Телескопик астрономия*

4) *махс.* Бик нык зурайтып күрсәтә торган. *Телескопик линза. Телескопик күзлек*

**ТЕЛЕСКОПИ́Я** *и. гр.* Телескоп ярдәмендә галәмне, галәм киңлекләрендәге җисемнәрне күзәтү эше

**ТЕЛЕСТУ́ДИЯ** *и. гр.-лат.* Телевидение студиясе. *Бу [Хәмит ага Төхфәтуллинга багышланган] тарихи язма телестудия архивында, бәлки, сакланадыр да әле...* Л.Хәмидуллин

**ТЕЛЕТАЙП** *и. ингл.* Телеграф ярдәмендә тапшырылган хәбәрләрне гади хәрефләр белән кәгазьгә баса торган аппарат. *Телетайп сүзен тыңлап барам. Тыңламаган көнем сирәктер.* Г.Афзал. *Туган көн бүген минем. Телетайп, телефоннар Җиткерсен якты хәбәр.* Р.Идиятуллин

**ТЕЛЕТАМАШАЧЫ** *и.* Телевизор караучы, телевизордан барган тапшыруларны тамаша кылучы кеше. *Күпсанлы хатларга, җәмәгатьчелек тарафыннан әйтелгән фикерләргә караганда, ул тапшыруларны телетамашачылар яратып карый.* Р.Миңнуллин

**ТЕЛЕФОН** *и. гр.* 1) Авазларны, сүзләрне ерак арага тапшыра һәм кабул итә торган элемтә төре. *Алар мондый [көчле буран булган] вакытта Казаннан тәмам аерылып кала: тимер юл яки су юлы булмаудан тыш, автомобиль һәм һава юлыннан да мәхрүм була, хәтта телефон элемтәсен дә югалта!* Т.Әйди

2) Шундый элемтәгә караган электротехник җайланмалар системасы. *Шулай иде дә, иртәнге сәгать алтыда телефон белән чакырып алдылар.* Т.Гыйззәт. *Кич телефон аша әйттеләр. Көндез үземә әйтергә курыкканнар, имеш.* Р.Вәлиев

3) Шул системаның төп өлеше – сөйләшүчене чакыру, сөйләү һәм тыңлау аппараты. *Нәкъ шул чак телефон шылтырады.* М.Насыйбуллин. *Кинәт кыр телефоны зыңлый башлады.* Ә.Айдар

**ТЕЛЕФОН-АВТОМАТ** *и. рус иск.* Сөйләшүчеләрне автомат рәвештә берәр номер белән тоташтыра торган телефон аппараты. *Айдан артык яшәп, чират күрмәдем, дип әйтер идем, телефон-автомат янында басып торгаларга туры килде.* И.Нуруллин

**ТЕЛЕФОНИСТ** *и. рус* 1) Телефон станциясе хезмәткәре. *Мин яшь чакта [авылның] почтасы бар иде, алты кеше эшли иде шунда: телефонист, телеграфист, бер почта йөртүче авыл буйлап, бере районга илтә-китерә, почта нәчәлниге; авыл уртасында, каршыда гына клуб иде.* М.Миначев

2) Телефон линиясе сузучы белгеч, элемтәче. *Бара торгач, юл буенда гына пычракка тезләнгән ялгыз бер кеше күренде. Ул телефонист булып чыкты.* Г.Бәширов. *Землянкада ике телефонист, бер денщик, ике вестовой.* А.Таһиров

**ТЕЛЕФОНИ́СТКА** *и. рус* Телефонист хатын-кыз. *Сафия өстәленә телефонистка кәгазь куя.* И.Юзеев

**ТЕЛЕФОНОГРА́ММА** *и. рус* Телефон аркылы әйтеп яздырылган рәсми хәбәр. *Подрядчыларның лаборатория начальникларына телефонограмма җибәрегез, иртәгә сезнең килүегезне көтеп торсыннар.* З.Дәүләтов

**ТЕЛЕФОНЧЫ** *и. к.* **телефонист**. *Шул ук төндә, 20 арбага төяп, мылтык һәм патроннарны, шулай ук телефон аппараты трубкасын һәм кулга алынган телефончы Ганиевны алып киттеләр.* Р.Вәлиев

**ТЕЛЛӘ** *и. гар. иск.* Утыз яки кырык сумлык алтын акча. *Бохарада җиде ел ачлык булды. Хәтта бер уч богдай бер теллә булды.* К.Насыйри

◊ **Теллә бай** Бай сәүдәгәр. *Бөтен гомерен бер тиен өчен сыкрап яшәгән һәм шул саранлыгы аркасында миллионнар җыйган теллә бай кинәт юмартлана, ун меңнәрчә акчасын һич кызганмый тота башлый.* А.Әхмәдуллин

**ТЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Тел ачылу, сөйләү сәләтенә ия булу. *Беренче сулышымнан алып, әле моннан 600 ел элек Литва кенәзлегендә телләнгән туган татар халкым мәдәниятендә тәрбияләнгәнмен.* Татар әдипләре

2) Сүзчәнләнү, гадәттәгедән күбрәк сөйли башлау; озак эндәшми торганнан соң сөйләп китү, авыз ачып сүз әйтү. *– Кулларың боз кебек булганчы, кайларда йөрдең болай, үскәнем, – дип телләнеп каршылады аны Нәфисәттәй.* Ф.Шәфигуллин

3) Телгә салышу, телдәрләнү, телдәрлек күрсәтү. *– Сатыла, бөтен нәрсә дә сатыла, – дип телләнде Митри карт.* Г.Гыйльманов

4) Каршы әйтү, кире җавап кайтару, телләшү. *Рәхмәт әйтеп, кешечә саубуллашып чыгып китәсе урында әрепләшеп, телләнеп, сүз көрәштереп торган була бит әле.* М.Хәсәнов. *– Тегендә кул астына эләксәң, изеп ташлый идем үзеңне. – Кем кемне изәр иде әле, – дидем мин, телләнеп.* Р.Зәйдулла

5) Ызгышу, тиргәшү, талашу. *Көчленеке замана. Тешләреңне кыса-кыса булса да чыдыйсың. Әхмәдигә дә телләнмәгән булса бик яхшы булган булыр иде дә бит, нишләтәсең инде аны.* Г.Камал

6) Телгә килү, кеше сыман сөйләү куәсенә ия булып китү. *Шунда телләнде өрәгем: «Син миңа кул орма, – ди, – Тыңла сүзне, тыңламасаң, дөньяда сау торма», – ди.* Г.Харис

**Телләнә башлау** Телләнергә тотыну. *Корбан бажасы да, посёлокның байтак кешесе телләнә башлагач, койрыкны сырт яккарак салу ягын карады.* Б.Камалов

**Телләнеп йөрү** Күп вакыт, төрле урында телләнү. *Әхмәдигә дә нигә кирәк иде инде шулай телләнеп йөрергә!* Г.Камал

**Телләнеп карау** Телдәрлек күрсәтергә омтылу

**Телләнеп китү** Кинәт телдәргә әйләнү, телдәрлек күрсәтү

**Телләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта телләнү; һәрвакыт, бертуктаусыз телләнү. *Аннары, өзгәләп ташлардай булып, телләнеп торган хатынга җикеренде.* М.Хәсәнов

**ТЕЛЛӘНҮЧӘН** *с. к.* **телләшүчән**. *Телләнүчән кыз*

**ТЕЛЛӘП** *рәв.* Сүз белән, теле белән. *Әмма моны Амантай телләп әйтеп биргәч, егетне тынычландырырга ашыкты.* Т.Әйди. *Шулай да ул аңар телләп җавап бирмәде.* Х.Ибраһим

**ТЕЛЛӘ́Ү** *ф.* Тел (*15 мәгъ.*) ясау. *Кульяулык читен телләү*

**ТЕЛЛӘШҮ** *ф.* Кисәтеп, шелтә белдереп яки үгетләп әйтүгә каршы кире җавап кайтару, сүз көрәштерү, әйткәләшү, әрепләшү. *Хатыннарның шулай телләшүе кәефен кырды бугай, юаш кына күренгән Гарифулла карт кызды да китте.* Ш.Янбаев. *Телләшү дигәндә, мин дә инде төшеп калганнардан түгел.* Г.Сабитов

**Телләшә башлау** Телләшергә тотыну. *Әмма үзләрен милиция түгел, ниндидер бер хатын-кызның гына җилтерәтүен күргәч, алар да шактый батырая төштеләр, телләшә үк башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**Телләшеп алу** Бераз телләшү. *Бүтән берәү ул сүзләрне әйтсә, җавабын да табар идем, телләшеп алырга да күп сорамас идем.* Т.Миңнуллин. *Киенеп куйгач, нигәдер телләшеп аласы килеп китте Алмазның.* И.Сираҗи

**Телләшеп китү** Кинәт телләшә башлау. *Безнең болай телләшеп китүебезнең ахыры-чиге юк иде.* Ф.Яхин

**Телләшеп тору** Һәрвакыт, гел телләшү; әле, хәзерге вакытта телләшү. *Ачылган авызыбызны ничек япканны сизми дә кала идек, кая ул телләшеп тору!* Г.Гыйльметдинова

**Телләшеп яту** Әле, хәзерге вакытта телләшү. *«Әткәйгә әйтәм!» Менә шушы ике сүз шиңдерә дә куя иде әтәчләнеп сугышып яки телләшеп яткан кешенең кикриген.* Ш.Җиһангирова

**ТЕЛЛЕ** *с.* 1) Теле булган. *Әллә кайда, кичәге көндә, кычытканлы тыкрыкларда онытылып калгангамы, елый да елый ун телле тальянка – олы күңелле нәни гандәлиб!* А.Тимергалин. *Бу тартмалар авыл малайларына кирәкле нәрсәләр белән тулы: буяу карандашлары, телле кармаклар, кубызлар, тагын-тагын бик күп әйберләр.* М.Хуҗин

2) Аңлашуга сәләтле, сөйләмгә ия булган. *Элек авылның телсезе-чукрагы, тилесе-диванасы, сакавы-тыңкышы, хәтта теле ачылган-ачылмаган баласы да ничектер үзенә генә хас телле иде.* А.Хәлим. *Бала бит тел белеп тумый, телгә булган мәхәббәт аның геннарына салына, ә баланы әти-әнисе телле итә.* И.Ихсанова

3) Алдында килгән, алда сүз барган халык, милләт атамасы белән берлектә шул халыкка, милләткә караган телгә ия булган. *Көньяк һәм Доннан көнчыгышрак өлеше төрки телле халык җирләре булган.* И.Хуҗин. *Татарлар күпләп яши торган шәһәрләр бар, ләкин үзебезнең гореф-гадәтле, телле, ул телгә ихтыяҗлы һәм ихтирамлы калалар юк бездә.* Н.Шәрифуллин

4) Билгеле үзенчәлекле, сыйфатлы теле булган. *Сания – тиз тузынучан, усал телле бичә.* М.Кәрим. *Ә бит ул асылда үтә йомшак күңелле ---, татлы телле, әдәпле сөйләмле кеше иде.* Р.Рахман

5) Телчән, телләшүчән. *Дөньяда ир белән хатын арасында ачуланышу да булыр, сөешү дә булыр. Шундый вакытта телле булудан сакланырга кирәк.* Г.Исхакый. *Әмир Хәсән әле малай-шалай, яшүсмер генә чагында бу кадәр үк телле түгел иде.* В.Имамов

6) Дөрес итеп сөйләшә белә торган, белдекле, сүзгә оста. *Бөтен эшкә хәзер яралы солдатлар белән Мөхәммәтҗан солдат шикелле, читтә йөреп, күзе ачылып кайткан теллерәк кешеләр хуҗа.* Г.Бәширов. *Теллерәк кызлар турыдан ярып, йөзгә бәреп тә әйтә: ир булган ирне хатын-кыз ташлап китми, чат ябышып ята, ди.* Г.Мөхәммәтшин

7) *күч.* Нинди дә булса мәгълүмат бирә торган. *Әмма Сәүбән өчен мәгарәдәге һәр таш, һәр ком, тузан бөртеге телле: --- бу тишек ике яктан да ачык. Утның яхшы януы, сулышның иркенлеге, һаваның тымызык җил булып йөреп торуы шул хакта сөйли.* Г.Гыйльманов

**ТЕЛЛЕЛЕК** *и.* 1) Нинди дә булса милли телгә яки телләргә ия булу. *Ул зур илдә соңрак кыпчаклар һәм татарлар гына калган, башкалары шул ук төрки теллелек сәбәбеннән халык була-*

*рак йотылганнар, татарларга, башка халыкларга кереп киткәннәр.* И.Хуҗин

2) Сөйләмдә аерым сыйфатларга ия булу. *Чөнки үз өйләрендә әниләре һәр эшне йомшаклык, тәмле теллелек белән җиңә килде.* Ф.Яруллин. *Флүрә әче теллелек белән яманаты чыккан нәселдән иде.* Р.Рахман

3) Телчән булу. *Әй шул кем дә җиңмәс теллелегең*

**ТЕЛЛЕ́-ТЕЛЛЕ** *с.* Кырыйлары киртләчләнеп торган, чук сыман уемнары булган. *Хисләремне үрәм Челтәр итеп күз-күз... Телле-телле бизәк – Күзәнәкле һәр сүз...* Л.Шагыйрьҗан

**ТЕЛЛЕ́-ТЕШЛЕ** *с.* Телгә усал, ачы телле, телчән. *Ак сакалыма хөрмәт күрсәтерләр, моңарчы телле-тешле кеше булмадым дип, авыл картлары әйткәч кенә, какмаслар мине дип ышанып барган булган идем...* А.Гыйләҗев. *Зөбәйдә түти телле-тешле хатын түгел.* Р.Батулла

**ТЕЛЛИ́М-ТЕЛЛИМ** *иярт.* Кыңгырау, чаң, шөлдер яки чиртеп уйнала торган уен кораллары чыгарган тавышларны белдерә. *Иртә белән тагын чаң сугып алдылар; теллим-теллим, димбум. Даң-доң-ң! Теллим-теллим, димбум, даң-доң-ң-ң-ң!..* М.Шабай

**ТЕЛЛИ́Н-ТЕЛЛИН** *иярт. к.* **теллим-теллим**. *Ул кара төймәгә ике мәртәбә басты, эчтә «теллин-теллин!» дигән матур тавыш ишетелде.* Ф.Садриев

**ТЕЛМӘКӘР** *с. диал.* Теленә салынучан, телләшүчән. *Телмәкәргә тап булма.* Мәкаль

**ТЕЛМӘКӘРЛЕК** *и. диал.* Телмәкәр булу. *[Мәрфуга:] И, шаярмасана, синең телмәкәрлегең бетмәс.* Җ.Фәйзи

**ТЕЛМӘР** *и.* Нотык. *Нуриҗан бәйрәмне ачык дип игълан итеп, леспромхоз ирешкән уңышлар, киләчәккә планнар турында кыска гына телмәр сөйләде.* З.Мурсиев

**ТЕЛМӘРЧЕ** *и.* 1) Оратор, нотык сөйләүче, сүз тотучы. *Акыллы, белемле телмәрчеләр сүз җәүһәрләренә мәкаль һәм әйтемнәрне, әкият-легендаларны, үләң-дастаннарны, үзләре өчен булса да, язып та алганнардыр, ихтимал, әмма ул язмаларның әлегәчә табылганы юк.* Р.Әхмәтьянов. *Сүз сөйләүчеләр, телмәрчеләр (элек патшалар да сүзне күп сөйләмәгәннәр, эш эшләгәннәр) күбәйде, хәтта аларга телмәр язучы махсус кешеләр – чиновниклар барлыкка килде.* Н.Нәҗми

2) Кош телен белүче, кошлар сайравына карап багучы күрәзә. *Тиле телмәрче булыр.* Мәкаль

3) *бор.* Тәрҗемәче, тылмач; дастан сөйләүче акын

**ТЕЛМӘТ** *и. диал.* 1) Телмәрче, күп һәм матур сөйләүче кеше

2) Татлы телле, тәмле телгә ия кеше. *– Кулың-аягың сызлаусыз булсын инде, Һарун абыкаем, – диде телмәт Равилә.* Н.Фәттах

**ТЕЛМӘ́-ТЕЛМӘ** *рәв.* **1.** Телемләп, телем-телем итеп. *Ачудан менә бу чырагачның сыртын телмә-телмә телергә уйлыйм.* Ф.Бурнаш

**2.** *с. мәгъ.* Теленгән; телләре булган. *Телмә-телмә тасма алдым Бөдрә чәчем үрергә.* Т.Гыйззәт

**ТЕЛМӘТЛЕК** *и. диал.* Телмәт булу сыйфаты. *Телмәтлеге билгеле инде*

**ТЕЛОГРЕ́ЙКА** *и. рус сөйл.* Сырма, фуфайка. *Телогрейка астында билдәге каешны да өзәрдәй булып эчәкләр селкенә, җитмәсә, рульдәге резин тоткыч шуып-шуып чыга.* Ф.Баттал. *[Карчыкның] Өстендә тапланып беткән телогрейка.* Ф.Кәримов

**ТЕЛСЕЗ** *с.* **1.** 1) Теле булмаган, тел кулланмаган; теле ватылган. *Ник эндәшмисең инде? Әллә телсез шунда син?* А.Мансуров. *Ләкин Хәлил абый артист буларак кинога төшүеннән канәгать булмый: телсез кинода, монда бас, тегендә бас, бер адым алга, бер адым артка, күзеңне ач, күзеңне йом, күккә кара, дип роль өстендә эшләүне аңламый да, кабул да итми.* Ә.Шакиров

2) Сөйләү куәсеннән мәхрүм булган, теле белән аңлаша алмый торган. *Телсез Әхтәм, төнлә район үзәгеннән кайтып килгәндә, ташуга тәгәрәп, кинәт телле булып китте.* З.Мәхмүди. *Сугыштан әти телсез, ишетми торган булып кайтты.* Кәеф ничек?

3) Сөйләү сәләтенә ия булмаган. *– Рәхмәт, хайван, – диде ир, йомшарып. – Син бел дә, мин бел бу гыйбрәтне, яме? Ярый син телсез әле.* Н.Гыйматдинова. *Ул [ак каен] бары тик кайчандыр үзе сокланып туймаган ике гашыйк җанның арадашчысы, алар мәхәббәтенең телсез шаһиты гына лабаса.* А.Әхмәтгалиева

4) Нинди дә булса сәбәптән аңлаша алмый торган. *Яшерелгән кылыч белән бергә «Коръән», «Кыйссасел-әнбия»ләр килеп чыга, ләкин мин телсез, аларны укый алмыйм. Гарәп имласы һәм теле тыелган.* А.Хәлим

5) *күч.* Сүз әйтеп үзен яклау мөмкинлегеннән мәхрүм калган. *Гайбәт теле озын була, дөреслек телсез булгач.* С.Баттал

6) *күч.* Телләшми, кычкырышмый торган. *Тавыш юк, Гыйбрәт батыр һич эндәшми, Телсез ул гомер буенча, сүзләшми.* Н.Думави

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Теле булмаган килеш; тел кулланмыйча

2) Дәшми-тынмый, берсүзсез. *Хуҗалар ишегалды бәрелешеннән аңгыраеп калган иделәр, нишләргә белмичә шактый ара телсез басып тордылар.* А.Гыйләҗев. *Каушап китүдәнме, әллә башка сәбәп аркасындамы, пешмәгән егет телсез тора бирде.* Ф.Яхин

**3.** *хәб. мәгъ.* Искә алмау, сүз кузгатмау. *Дөрес, Кәүсәриянең күршеләре, коллегалары бу хакта телсез: көтмә дип тә, исән булырга мөмкин дип тә сүз кузгатып, ханымның күңелен телгәләмиләр.* З.Мурсиев

◊ **Телсез калдыру** Нык гаҗәпләндерү, шаккаттыру. *Яшь килен, көтү куып кайтучы бөтен хатыннарны телсез калдырып, көянтә-чиләк белән су буеннан Шәяхмәтләр капкасына кайтып керде.* М.Мәһдиев. **Телсез калу** Гаҗәпләнүдән, куркудан, кинәтлектән дәшми тору, сүз әйтүдән гаҗиз булу. *Балаларын каршыларга килгән әтиәниләр, әби-бабайлар бакчада куркан өерләнә күреп телсез калдылар.* Ф.Баттал. *Кыз алдында егет үзе дә бермәл телсез калган, нәрсә дип җавап кайтарырга да белмичә аптырап тора иде.* Ф.Хөсни

**ТЕЛСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Сөйли алмый башлау, телдән калу, сөйләшү сәләтен югалту. *Аның артыннан нәрсәдер әйтергә дип авыз ачкан Бәдәр Җиһанының*

*авызыннан бер сүз дә чыкмады. Ул тагын телсезләнгән иде...* И.Шиһапов

2) Берәр сәбәп аркасында дәшмәс булу

**Телсезләнеп калу** Нindидер вакыйгадан, сәбәптән соң телсезләнү. *Яңадан баш алырга маташкан коммунистлар гына бу хакта авызларын ачып сөйләп маташкан иделәр, сайлаулардан тәгәрәшеп төшкәч, ахырда, тәмам бөрешеп, телсезләнеп калдылар.* Ф.Яхин

**ТЕЛСЕЗЛЕК** *и.* Телсез булу күренеше. *Телсезлек ялган сөйләүче телдән яхшырак*

**ТЕЛСЕ́З-ӨНСЕЗ** *с.* **1.** 1) Сөйли дә алмый, бернинди аваз да чыгара алмый торган. *Нәфисә һаман телсез-өнсез иде.* Г.Гыйльманов

2) Телле-тешле булмаган. *Телсез-өнсез, үксез яшь кызларны кызганудан аның йөрәге кысылып-кысылып куйды.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* Дәшми-тынмый, берсүзсез. *Нигә шулай телсез-өнсез җебеп төште?* А.Гыйләҗев

◊ **Телсез-өенсез калу** Көтелмәгән бер хәлдән, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырап калу. *Телеграмманы алдым да телсез-өнсез калдым.* А.Гыйләҗев

**ТЕЛСЕ́З-ТЕШСЕЗ** *с. к.* **телсез** (*6 мәгъ.*). *Шаһит исә – телсез-тешсез юаш адәм.* М.Кәрим

**ТЕЛСЕ́З-ЧУКРАК** *с.* Ишетми һәм сөйләшми торган. *Нурия янына, ире телсез-чукрак Ишмаковны ияртеп, Җәүһәр керә.* А.Гыйләҗев

**ТЕ́Л-ТЕЛ** *с.* **1.** *к.* **телле-телле**. *Буа тел-тел булып, яр-ерганак араларына тикле сузылып кергән иде.* Х.Сарьян

**2.** *рәв. мәгъ.* Телләр (*13, 14 мәгъ.*) рәвешендә, буй-буй, телем-телем итеп

**ТЕЛ-ТЕШ** *җый. и.* Тиргәш, ызгыш, талаш, гауга, җәнҗал. *Шушы көнгә кадәр бер генә тел-тешкә килгән дә юк, Аллага шөкер.* Н.Фәттах

◊ **Тел-теш тидерү** Каты итеп шелтәләү, яманлау, гаепләү, тел сузу. *Сакманов --- ислам тәгълиматына сукырларча табынмаса да, Тәңре белән бил алышуны, аңа тел-теш тидерүне хупламый иде.* Т.Галиуллин. *Күрәсез: килбәте, шулай ук табигате-холкы да тел-теш тидерерлек түгел.* С.Сабиров

**ТЕЛ-ТЕШЛЕ** *с.* 1) Гаугачыл, тиргәшә торган. *Тел-тешле кеше*

2) Тавышлы, ызгышлы, ризасызлык тудыра торган. *Бу эшнең азагы тел-тешле булмасын*

**ТЕЛ-ТЕШСЕЗ** *с.* Тел-теше булмаган, телләшми торган, карулашмаучан, күндәм. *Безнең хәтердә сабыр, телтешсез, хезмәт сөючән, үзләренең рәнҗетелүләре өчен беркемнән дә хисап таләп итмәгән бу изге җаннар менә шундый булып сакланыр.* Т.Кәримов

**ТЕЛҮ** *ф.* 1) Тигез яссылык ясап кисү, юка кисәкләргә яру, телем итү. *Юка телү дә бер һөнәр.* Мәкаль. *[Ана] Чәен куя, өстәл хәстәрләп, икмәген, лимонын телә...* Г.Гыйльманов

2) Өслекне тетеп, ярып җибәрү. *Нурулланың сыңар кулы һавада әллә нинди хәрәкәтләр ясап ала, һаваны бер телә, бер болгата...* А.Гыйләҗев. *Күкне телә тагын хәтәрләре яшеннең.* Р.Бикбаев

3) Нәрсәне дә булса буй-буй кисү, телемнәр ясап кискәләү. *Әнисе чыраларны, бәйләү энәседәй юка итеп, тик кара чыршылардан гына телә, чөнки кара чыршыдан телгән чыралар бер дә галәмәт яналар.* А.Хәсәнов

4) Чабу, тураклау. *Боларны хәзер сафка – нөгәргә туплау бөтенләй мөмкин түгел, ә магуллар, шуннан аркаланып, качакларны кылыч белән дә, сөңгеләр белән дә телә, турый, тетә генә иде.* В.Имамов

5) *күч.* *Җан, йөрәк, күңел* сүзләре белән берлектә: борчу, газаплау. *Аның күңелен әнә шул сораулар телә иде.* В.Нуруллин. *Кешенеке кештәктә шул, үзеңнеке җанны телә.* Г.Исхакова

6) *күч.* Бик каты кыйнау (камчы, чыбык һ.б.ш. белән). *Казаклар ир-атны камчы белән теләләр.* Х.Кәрим

**Телә бару** Торган саен ныграк телү. *Кыз йөрәкне калҗа-калҗа телә бара.* М.Шабаев

**Телә башлау** Телергә тотыну. *Урыннарыбызга җайлашкач, ипиен чыгарып телә башлады.* Ф.Баттал. *Таулар өстендәге соры тынлыкны автомат тавышлары телә башлады: та-та-тат-та!* Р.Низамиев

**Телеп алу** Кинәт, бик тиз телү. *Соңарудан туган үкенеч тойгысы малайларның бәгырен телеп алды.* А.Гыймадиев

**Телеп җибәрү** Кинәт, искәрмәстән телү. *Куян имән бармагымның төбеннән шундый зур телеп җибәргән, хәтта карарга куркыныч.* Н.Исәнбәт. *Үткен пычактай телеп җибәрде бу сүзләр Рәшидәнең йөрәген, тирән сызланудан йөзе сытылып китте.* Ә.Еники

**Телеп кую** Алдан телү; бер тапкыр телү. *Мул итеп әпекәй телеп куйган.* Д.Булатова. *Әбисенең телеп куйган чырасын алып, учак ялкынында кабыза да айкый башлый.* К.Җәмит

**Телеп ташлау** Тиз-тиз кискен хәрәкәтләр белән телү; уйламаганча, көтмәгәнчә телү. *– Менә ничек телеп ташлаганмын, – дип, теге батистын алып күрсәтте [Хәят].* Ф.Әмирхан. *Әгәр күзләренә күренсәң, болар сине шул минута кавын сыман телеп ташлаячак.* В.Имамов

**Телеп тору** Бертуктаусыз телү; хәзер телү. *Әлбәттә, безгә ул [юка, зәгыйфь сыер] юаныч китермәде, әнкәй җанын телеп торган бер камчы гына булды.* Л.Хәмидуллин

**Телеп узу** Кинәт телү. *Шул мизгелдә җанны кисеп, әрнүле бер сизенү телеп узды.* М.Галиев

**Телеп үтү** *к.* **телеп узу**. *Йөрәкне нindидер әрнү телеп үтте. Телеп үтте дә югалды.* М.Кәбиров

**ТЕЛЧӘН** *с.* Үтемле итеп әйтергә, тарткалашырга яки җорланырга оста, сүзчән. *Бу телчән хатынның басып килеп керүе аеруча Хәдичәгә ошамады булса кирәк.* М.Хәсәнов. *Яшь чакта да шулай усал, телчән иде. Тешләре төшеп беткән, һаман шул «пычак тел Мәрзия» булып калган.* Ф.Абдуллин

**ТЕЛЧӘНЛӘНҮ** *ф.* 1) Телчән булып китү. *Ул [Йосыф Акчура] телчәнләнеп яшәү белән генә чикләнми, бу телне саклауга да шундый ук җитди игътибар юнәлтә.* М.Гайнетдин

2) Каршы сүз әйтә торган булып китү. *Әнисе көннән-көн усаллана, телчәнләнә, ә әтисе исә үзалдына йомыла, суына бара.* З.Фәйзуллин

**ТЕЛЧӘНЛЕК** *и.* Телчән булу. *– Мин – сәүдәгәр, – ди. – Холкым-*

*табигатем, телчәнлегем белән разведчик була алмыймдыр...* Р.Мостафин

**ТЕЛЧЕ** *и.* Билгеле бер телне (телләрне) яки гомумән тел мәсьәләләрен тикшерү белгече; тел галиме, тел белгече, лингвист. *Бу урында этнограф һәм телче галим Ф.Баязитова тарафыннан информантлардан язып алынган Май чабу турындагы хикәяләүләрне китереп узу урынлы булыр.* Р.Ягъфәров

**ТЕЛЧЕК** *и.* 1) Кечкенә тел. *Куян кетер-кетер агач кайрысы кимергән, ә песи нәни кызыл телчеге белән чепер-чепер сөт эчкән.* А.Алиш

2) Телне хәтерләтә торган теләсә нинди кечкенә әйбер

3) *бот.* Кыякча, кыякчык. *Телчек яфрак белән җиңсә арасына урнашкан 2–6 мм озынлыктагы башаксыман чәчәк төркеме 4–10 башакчыктан тора.* Агулы үсемлекләр

4) *анат.* Хатын-кызларның тышкы җенес әгъзаларындагы кечкенә үсенте

**ТЕЛЧЕЛЕК** *и.* Телче эшчәнлеге. *Галимҗан Ибраһимовның телчелек, тарихчылык һәм тәнкыйтьчелек эшчәнлеге*

**ТЕЛЬНЯ́ШКА** *и. рус* 1) Аклызәңгәрле буй-буй юллы киҗе-мамык трикотаждан тегелгән эчке күлмәк – башта матрос, соңрак башка гаскәр төрләрендә форма киеме элементы. *Башына – ике озын тасмалы берет, өстенә тәненә сыланып торган тельняшка һәм чем кара бушлат кигән кызны бер күрүдә үз әнисе дә таный алмас иде, мөгаен.* Р.Зарипов

2) Гомумән шуңа охшаш кием төре

**ТЕЛЬНЯ́ШКАЛЫ** *с.* Өстенә тельняшка кигән. *Алар камерасында баштанаяк кара киемле, буй-буй зәңгәр тельняшкалы матрос бар иде.* Р.Кәрами. *Тельняшкалы егет иптәшләренә карап алды да тамагын кырып куйды.* А.Хәсәнов

**ТЕ́МА** *и. лат.* 1) Сүз, инша, бәхәс, әсәр һ.б.ш.нең эчтәлек юнәлеше, тасвирлау яки бәян итү объекты. *Ни өчен бу тема язучыларны шулкадәр үзенә тарта соң?* Р.Миңнуллин. *Әсәрләрдә шулай ук мәңгелек тема – мәхәббәт темасы да ачык чагыла.* А.Фәләх

2) Мәкалә, чыгыш, доклад һ.б.ш.ның башындагы исеме. *Сочинение язар өчен, миңа өч тема тәкъдим иттеләр, --- берсе хәтеремдә: «Советлар Союзы – тынычлык терәге» дигән ирекле тема иде.* В.Нуруллин

3) Музыкаль әсәрдә яки аның берәр кисәгендә үсеш нигезе итеп алынган төп көй, мотив. *Халыкка бүген нинди тема, нинди көй кирәклеген тоеп, шуны тәкъдим итәргә тырышам.* Кәеф ничек?

**ТЕ́МАЛАП** *рәв.* Темаларга аерып. *--- шул бүлекне үз эчендә темалап бүлгәндә, 11 сәгать килеп чыга.* А.Әхмәдуллин

**ТЕ́МАЛЫ** *с.* Нинди дә булса темага багышланган. *«Халкыбызның милли бизәкләре» дигән темалы хезмәт дәресендә малайлар – түбәтәйләр, ә кызлар алъяпкычлар бизәү белән шөгыльләнделәр.* А.Ибраһим

**ТЕ́МАЛЫК** *с.* Аерым бер темага яраклы. *Берничә темалык материал*

**ТЕ́МАЛЫЛЫК** *с.* Тематикасы булган. *Күп темалылык*

**ТЕМА́ТИК** *с.* 1) Гомуми яки билгеле бер темага багышланган; тема яки темаларга карап билгеләнгән. *Шулай ук студиянең тематик планыннан чыгып, язучыларга оригиналь либреттолар язарга тапшырды.* М.Җәлил. *Зөлкарнәй университетта укыган елларында ук инде мәңгегә онытылган яисә өр-яңа яңгыраш биреп ясалган сүзләрне картотекаларга аерып, тематик җирлектә төзи башлаган булган.* М.Галиев

2) Тематикага бәйләнешле, тематика ягыннан караганда ачыклана, беленә торган. *Алар күләм ягыннан күп, тематик яктан бик бай бер лексик катламны берләштерәләр.* Г.Мөгътәсимова

**ТЕМА́ТИКА** *җый. и. лат.-гр.* Төрле темалар тупланмасы. *Ә инде тематика ягыннан совет чоры драматургиясенең үзенә кадәрге чорларга караганда байрак һәм төрлерәк булуын күрербез.* А.Әхмәдуллин. *Әмма әле аларның да тематикасы, материалы нигездә соңгы дәвер белән чикләнелә.* Х.Миңнегулов

**ТЕМА́ТИКАЛЫ** *с.* Билгеле тематикасы булган; үзенә хас махсус тематикасы булган. *Алар [спектакльләр] актив заманча тематикалы, гражданлык хисләре булуы белән башкалардан нык аерылып торды.* Д.Гыймранова

**ТЕМБР** *и. фр.* Бер үк югарылыктагы авазларның тавыш дулкыннары төрлелеге белән аңлатыла торган төсмерләнүе, һәрбер тавышның, уен коралының үзенә генә хас булган сыйфаты, аваз төсмере, аһәң үзенчәлеге. *Музыка белгечләре аны нинди тембрга да кертергә белмичә аптыраарлар иде.* М.Галиев

**ТЕ́МБРЛЫ** *с.* 1) Билгеле бер тембрдагы. *Ришатныкы – йомшак тембрлы көчле куе баритон, Мөслимнеке – көмеш сыман йомшак лирик тенор.* Т.Әйди

2) Тембрга карап аерымлана торган. *Тавыш уникаль тембрлы булгач, радиога язылганда, аның дикциясенә бәйләнергә кыймыйлар иде.* М.Макаров

**ТЕМИ** *и. гар. диал.* Бозык теләк, нәфес, тәмгы. *[Әхәт] әнә шул пычрак «буйдаклар фатиры» ачкычына темиен сузып кына путёвка артыннан чаптымы?* А.Гыйләҗев

**ТЕМП** *и. ит.* 1) *муз.* Музыкада, әсәрне башкарганда, тактлар алмашыну тизлеге. *Егетләр музыканың темпын киметтеләр, гимнастика ясаучылар барыбер ритмга ияр алмыйлар иде...* Казан утлары. *Кызу темплар. Салмак темплар*

2) Нәрсә дә булса башкарылганда, нинди дә булса эш, бирем һ.б.ш. үтәлгәндә, процесс агышының тизлек дәрәҗәсе. *Тукай поэзиясендә «татарлашу» процессы гаять кызу темп белән бара.* И.Нуруллин. *Бөтен республиканы электрлаштыру шундый темплар белән башкарыла.* Җ.Юныс

**ТЕМПЕРА́МЕНТ** *и. лат.* 1) Кеше характерының күңел ярсынуы, дәртсенү көче, хәрәкәтчәнлек дәрәҗәсе белән билгеләнә торган тотрыклы психикфизиологик, рухи үзенчәлекләре. *Ират темпераменты һәм хатын-кыз тыйнаклыгы милли хореографиянең нигезен тәшкил итә.* М.Кыямова

2) Реакция тизлеге һәм аның характеры белән билгеләнә торган психотип. *Яхшы һәм яман темпераментлар булмый. Төрле темпераментлы кешеләр бөтен дөньяга фән, сәнгать һ.б. өлкәләрдә танылa алганнар. Мәсәлән: Суворов (холерик), Крылов (флегматик), Гоголь (меланхолик), Энгельс (сангвиник).* Р.Төхвәтуллина

3) *күч.* Кызулык, дәртлелек, энергия. *Кеше язмышын хәл иткәндә, темперамент – начар киңәшче.* Г.Әпсәләмов. *Гомерен мәдәниятқә, рухи агартуга багышлаган Фоат Зарипов тарафыннан тудырылган образлар кабатланмас, бары тик аның эчке матурлыгы, темпераменты белән баетылганга гына үзенчәлекле булуы белән аерылып тора.* Л.Зарипова

**ТЕМПЕРА́МЕНТЛЫ** *с.* 1) Аерым бер темпераментка ия булган. *Комиссиядә төрле холыклы, төрле темпераментлы депутатларның булуы да рәис файдасына.* Р.Миңнуллин

2) *күч.* Дәртле, энергияле. *Мин хатын-кызның темпераментлы булуын мәҗлестә генә яратам.* Г.Әпсәләмов. *Бу дәртле, темпераментлы, энергияле җыр хәзерге көндә дә беркемне ваемсыз калдырмый.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Кызып китүчән, ярсучан. *Ф.Сәйфи бик темпераментлы кешеләрдән иде. Ул урыныннан сикереп торды, гадәтенчә, кызып, кычкырып сөйләргә керешә.* А.Шамов

**ТЕМПЕРАТУР** *с.* Температурага бәйле, температурага нигезләнгән. *1983 елда биредә иң салкын температур рекорд теркәлгән – 89 градус.* Кызыл таң. *Температур тирбәнешләр*

**ТЕМПЕРАТУ́РА** *и. лат.* 1) Нәрсәнең дә булса җылыну дәрәҗәсе. *Бер үк вакытта һава температурасы да ун градус җылыдан бер көн ярым вакыт эчендә минус уннар тирәсенә «мәтәлләде»...* Р.Гаязетдин

2) Сәламәтлек күрсәткече буларак, кешенең тән җылылыгы дәрәҗәсе. *Сунчәләй кан коса, югары температурадан изалана.* Р.Мостафин. *Берәр сәгать үттеме икән, кызның температурасы төште, күзләрен ачты.* Н.Әхмәдиев

**ТЕМПЛЫ** *и.* Билгеле бер темпта барган, башкарылган һ.б.ш. *Бу сурәт катлаулы сыйныф көрәшендә һәм көндәлек кызу темплы социализм төзелеше эчендә күрсәтелергә тиеш.* М.Җәлил. *Әйе, безнең заман – җитез темплы, кызу, катлаулы, хәтта стресслы заман.* Г.Хөсәенов

**ТЕМСЕНҮ** *ф. диал.* Нәфесеңне сузу, тәмгы сузу. *Булмастайга темсенмә дә, күрсенмә дә.* Мәкаль. *Чакырулы булгандырмы, үзе темсенеп килгәндерме – анда Шәйхи дә бар иде.* В.Нуруллин

**ТЕНДЕНЦИОЗ** *с.* 1) Чынбарлык күренешләрен берьяклы, бер якның мәнфәгатьләреннән чыгып кына, бер якны күзәтеп кенә, гаделсез яктыртa торган. *Элек кайберәүләр: «Тукай шәпме, Гафури шәпме?» – дигән сыман тенденциоз мәсьәләләр күтәреп, безне каракаршы куярга маташтылар.* С.Кудаш. *Ләкин ул тарих фәнендә беренчеләрдән булып, Мәскәү – Казан мөнәсәбәтләрен тар кысаларда гына карамыйча, аны, тенденциоз юллар белән булса да, Аурупа халыклары багланышлары шартларына яраклаштырырга омтыла.* Казан утлары

2) Тар караштан чыгып, билгеле бер мәнфәгатьләрне бик беркатлы гына аңлаган яки тәгъбирләгән, әйткән, күрсәткән. *Бердән, Г.Ибраһимовның ул фикерләре, югарыда әйтелгәнчә, әдәбият белемендә романтизмга тенденциоз караш, гомумән тискәре мөнәсәбәт хакимлек иткән бер чорда әйтелгән.* М.Хәсәнов

**ТЕНДЕНЦИОЗЛЫК** *и.* Тенденциоз булу. *Бу тенденциозлык тикшерү өчен шигырьләр сайлауда ук чагыла.* М.Хәсәнов. *Урыны белән ул биредә тенденциозлык та күрсәтә.* Х.Миңнегулов

**ТЕНДЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Омтылыш, үсеш юнәлеше, нәрсәгә дә булса тартылганлык. *Архив документларына нигезләнеп, аерым фактларга һәм вакыйгалар нисбәтендә соңгы чор татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен ачыкларга тырыштым.* Р.Фәйзуллин

2) Билгеле бер вакыйганың, күренешнең үсешендә күзәтелгән анык юнәлеш. *Хәзерге әдәбият белемендә аерым тенденцияләрне билгеләү омтылышлары булды инде.* Ә.Закирҗанов

3) Башлыча сәнгатьтә һәм әдәбиятта чагылыш тапкан зур иҗтимагый теләк, иҗтимагый идея. *20 нче еллардагы татар әдәбиятында физик [яктан] көчле һәм рухи [яктан] горур геройны сурәтләргә омтылыш гомуми бер тенденциягә әйләнде дияргә мөмкин.* Г.Халит

4) *кит.* Сәнгать әсәренең үтә анык идея юнәлеше, тенденциозлыгы. *Анда беренче басмада булган әхлакчылык тенденцияләре бик нык киметелеп, яхшы ук нык эшләнгән художество образлары аша тормышка тәнкыйть күзе белән карау һәм критик реализм методы ачык сизелеп тора.* М.Гали

**ТЕНДЕ́НЦИЯЛЕ** *с.* 1) Аерым бер тенденциясе булган, бер тенденция сизелгән. *Зыя сәнгатьнең бу көнге тормышта актуаль һәм ачык тенденцияле роль уйнаган тармакларыннан бигрәк, аның музыка, рәссамчылык кебек тармагын артык күрә.* Г.Нигъмәти

2) *күч.* Берьяклы, бер принцип күзлегеннән чыгып кына каралган, тенденциоз. *Авторның субъектив һәм үтә тенденцияле мөнәсәбәте әсәрнең ышандырырлык булмавын китереп чыгара.* М.Җәлил

**ТЕНДЕ́НЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Тенденцияле булу. *Шул ук вакытта Туфан ага, аеруча үзенең соңгы чор иҗатында, төз схемалардан, бер яклы бәяләүләрдән, тенденциялелектән читләшә иде.* Сәхнә

**ТЕ́НДЕР** I *и. ингл.* 1) Су, ягулык һ.б.ш. төяп йөртелә торган паровозга тагылган махсус вагон яисә паровозның су, ягулык һ.б.ш.ны саклау өчен билгеләнгән арткы өлеше. *Кинәт ниндидер бер кеше тендерга сикереп менде дә теге трубаны тотып та алды, ул труба борылып йөри икән, ул аны үзенә, тендерга таба борды.* А.Алиш

2) Бер мачталы киң җилкәнле судно

3) *тар.* Ярдәмче сугыш көймәсе

**ТЕ́НДЕР** II *и. ингл. икът.* Товар белән тәэмин ителүдә: тәкъдимнәрне конкурентлы формада сайлап алу яисә тәкъдим итү күренеше. *Ә буа төзүгә махсуслашкан җирле предприятие, барлык таләпләргә җавап биреп, тиешле документация әзерләп, экспертизаларны үтсә дә, тендердан төшеп кала.* Кызыл таң

**ТЕ́ННИС** *и. ингл. спорт* Мәйданчыкны икегә аерып торган ятьмә аша кечкенә тупны махсус калак белән ыргытып уйнала торган спорт уены. *Аннан сары шар килеп чыкты. Үзе зур да түгел, теннис тубы хәтле генә.* Т.Кәримов. *Сингапур кешесе атнага ике-өч мәртәбә теннис кортына барып ва-*

*кыт үткәрә, чит илләргә сәяхәтләргә барып кайта.* Ә.Рәшит

**ТЕ́ННИСКА** *и. рус* Гадәттә трикотаждан тегелә торган кыска җиңле күлмәк. *Рифатның яшел чалбарына кыстырылган кыска җиңле җете ак тенниска кесәсендә «Әпипә» көе яңгырады.* К.Кәримов

**ТЕ́ННИСЧЫ** *и. спорт* Теннис уйнаучы спортчы. *«Связист» спорт клубы теннисчылары, бер уеннан башка барысында да җиңеп, вакытыннан алда Русия чемпионы исеменә лаек булды.* Кызыл таң

**ТЕ́НОР** *и. ит. муз.* 1) Ир-атка хас нечкә тавыш. *Аның тавышы җәйге иртәдә искән җылы җил шикелле йомшак, ягымлы бәрхет тенор иде.* Р.Сәйфуллин. *Ногайбәк ага матур тенор белән җырлап та җибәрде: «Карурманга кердем, ай, кич кенә...»* А.Хәсәнов

2) Шундый тавышлы җырчы, солист. *Отелло партиясе – тенорлар репертуарындагы иң катлаулы партияләрнең берсе.* Г.Бәйрәмова

**ТЕНТ** *и. ингл.* Кояштан һәм яңгырдан ышыклану өчен, брезент ише материалдан ясалган япма. *Габделбәр капчыгыннан палатканың янган өлешенә кушып тегәргә дигән тент кисәген чыгарды.* А.Хәсәнов. *Тент су читенә җәеп салынды, аның дүрт почмагына арканнар тагылды, ә катерлар йөзмә краннны борып, борыны белән тентнең нәкъ уртасына каратып куйдылар.* З.Мурсиев

**ТЕНТҮ** I *ф.* Яшерелгән яки яшерелергә мөмкин булган берәр нәрсәне эзләп, кешенең киемен, йорт-җирен һ.б.ш. капшап, актарып, җентеклеп карап чыгу. *Бөтен авылны тентеделәр.* Г.Исхакый. *Хәйрулланың кесәләрен тентегәннәр иде, бер кесәсеннән – Колчак армиясе офицеры билеты, икенчесеннән Коммунистлар партиясе билеты чыкты.* В.Нуруллин

**Тентеп бетерү** Ахыргача тентү. *Мәдрәсәдә кунучыларны тентеп беткәч, фатирдан йөреп укучыларның һәммәсене тентеп, адресларыны язып алдылар.* Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар

**Тентеп тору** Гел, әледән-әле яки әле, хәзер тентү. *Хәзер күп алар бу тирәдә. Ә монда аларга карата закон каты, шулар аркасында авылны да гел тикшереп, тентеп торалар.* Ф.Бәйрәмова

**Тентеп чыгу** Булдыра алганча бөтен җирне тентү. *Каютамдагы барлык китапларымны карап, тентеп чыктылар.* Р.Вәлиев. *Рафис, аларга якынаеп, һәркайсының кесәләрен тентеп чыкты, документларын һәм акча янчыкларын алып, өстәлгә салды.* Ф.Яхин

**Тенти башлау** Тентергә керешү. *Аның ай-ваена карамый тенти башлыйлар.* Һ.Такташ. *Әгәр тегеләр килеп, алай-болай тенти башласалар, менә бу пачкаларны сиздерми генә тәрәзәдән ат.* Г.Әпсәләмов

**Тенти бирү** Бернигә карамый тентү. *[Әхмәтҗан:] Ихтыяр үзегездә, тенти бирегез.* Т.Гыйззәт

**ТЕНТҮ** II *и.* Яшерелгән яки яшерелергә мөмкин булган берәр нәрсәне эзләп, кешенең киемен, йорт-җирен һ.б.ш. капшап, актарып, җентеклеп карап чыгу эше. *Үзе берәр яры чыгып китү белән, аның өендә тентү үткәреп, язмаларын оятсыз рәвештә алып китә торган булганнар.* А.Тимергалин. *Тулай торакларны, кабинетларны, уку бүлмәләрен тентү, эзләнүләр китте.* Ф.Бәйрәмова

**ТЕҢ** *иярт.* 1) Кечкенә металл әйберләрнең бер-берсенә бәрелүеннән чыккан тавышны белдерә. *Әнә таныш сәгать. Тең! Тең! Авыр хәрәкәт белән гомер саный.* М.Мәһдиев

2) Уен коралы кылына чирткәндә, кагылганда чыккан тавышны белдерә. *Мандолина кылына кагылуга, тең иткән тавыш чыгара*

**ТЕҢГЕЛ** *и.* 1) Үзенә әйләнә торган деталь утыртып, кидереп куела торган күчәр; кендек, үзәк, кадак. *Татар телендә кайбер сөйләшләрдә орчык дип тегермән ташының теңгелен, ягъни күчәрен дә атыйлар.* Р.Әхмәтьянов. *Кайчы теңгеле*

2) Берәр нәрсәнең әйләнә торган детале; кечкенә тәгәрмәч, ролик

**ТЕҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* Теңгел-теңгел иткән тавышлар чыгару. *Кечкенә кыңгырау теңгелдәү. Шөлдер теңгелдәү*

**ТЕҢГЕ́Л-ТЕҢГЕЛ** *иярт. к.* **тең**. *Теңгел-теңгел итү*

**ТЕҢКӘ** *и.* 1) Нерв. *Имчеләр, теңкәдән, диләр, теңкәсен теңкәдер дә, Көләч чагымда күз кабагым Алай тартышмый бер дә.* Н.Арсланов. *Әсирләрне тезәләр, исемлекне укыйлар, әмма һәр икәүне атып, өченчене исән калдырып, борчак өстенә тезләндерәләр ---. Тәүбә иттереп, әсирдә теңкә өянәге кузгаталар.* А.Хәлим

2) Аерым тәгъбирләр составында: җан, рух, кәеф; көч, хәл. *Нуркәй, кызып, буза белән кружкасын селкеп-селкеп, Ксукның теңкәсенә үтәргә теләгән позада, бөтен тавышына җырлап җибәрде.* Һ.Такташ. *«Теңкә» дигән сәер сүзнең дә гамәлдә түземлек, сабырлык мәгънәсендә икәнен аңладым шул араларда, юкса мин аны, күзгә күренеп тормагач, эчтәге бавыр я йөрәк кебегрәк берәр әгъза микән, дип баш вата идем.* Г.Якупова

◊ **Теңкәгә тию** Җанга тию, газаплау; борчу, бимазалау; туйдырып бетерү. *Ике малайның берсе – Рөстәмгә таныш өтер Вәли, бозыклыгы белән укытучыларның теңкәләренә тигән гаять хәйләкәр, хулиган Вәли иде.* Г.Кутуй. *Хәлилнең гаять көнче кеше булуын беләсезме икән? Шул гадәте белән теңкәләремә тия, вакытсыз гүрләргә илтеп тыга инде.* Т.Галиуллин. **Теңкә кору** Газаплану, җәфалану; аптырап, йөдәп бетү. *Үзсүзле, тәкәббер шәһәр кызын күңеленнән ул хәтта яманлап куйды. Әле хәзер тыңламый әйткәнне, эшли башлагач, теңкәң корып бетәр моның белән!* Н.Фәттах. – *Кая монда демократия? – димен бит инде, парин, теңкәм корудан аптырагач.* Ф.Баттал. **Теңкәне корыту** Аптырату, газаплау, җанга тию. *Ул да түгел, кырыкка төрләнеп, ыжгырып-ажгырып торган, җан ияләренең теңкәсен корыткан зәмһәрир салкыннары, кузачкысыз бураннары белән кыш җитә.* М.Хәсәнов. *Безнең теңкәне корыткан хөрәсән ялкавы – кемнеңдер иң якын кешесе.* Ф.Яруллин

**ТЕ́Ң-ТЕҢ** *иярт. к.* **тең**. *Үз тавышына игътибар итүләрен күреп, кыңгырау чәчәк тагын чыңлап куйды: «Тең-тең-тең!»* Ф.Зариф

**ТЕҢ-ТЕ́Ң ИТҮ** *ф. к.* **теңгелдәү**

**ТЕОДОЛИТ** *и. гр.* Геодезик һәм астрономик тикшеренүләр вакытында кулланыла торган почмак зурлыгын үлчәү коралы. *Тагын да бер айдан инде Кураишта теодолитларын аскан геодезистлар күренде.* З.Мурсиев. *Теодолит окулярын линейка тотучыга таба борганда, басу буйлап чабучы күренгән кебек тоелды.* И.Кашфразыев

**ТЕОКРА́ТИЯ** *и. гр.* 1) Руханилар кулында булган сәяси хакимият идарәсе, руханилар диктатурасы

2) Идарә ителүе шундый формада булган дәүләт. *Борынгы теократияләр*

**ТЕО́ЛОГ** *и. гр. дини* Теология белгече, илаһиятчы. *Габдулла Утәмешев алдынгы карашлы, белемле, зыялы шәхес булган, теология мәсьәләләренә багышланган берничә китап язган.* Г.Мөхәммәтшин. *Халык һәм галимнәр вә теологлар арасында нинди бәхәсләр генә бармасын, соңгы сүзне ул әйтәчәк.* М.Хәбибуллин

**ТЕОЛО́ГИК** *с.* Теологиягә караган, шуңа нигезләнгән. *Күренә ки, Кандинскийның теоретик концепциясе теологик карашлардан да азат түгел.* К.Гыйззәтов

**ТЕОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Дин белеме, илаһият. *Син теологиядән бераз хәбәрдардыр бит?* М.Маликова. *Барлык уку йортларында да студентлар өчен теология фәнен укытуны уку программасына кертү кирәк.* Кызыл таң

**ТЕОРЕ́МА** *и. гр. мат.* Исбатлау юлы белән раслана торган математик кагыйдә. *Укытучы кушканнарны гына түгел, алдагы дәрестә үтелергә тиешле теоремаларны, физика законнарын һәм шул теоремаларга, шул законнарга нигезләнгән мәсьәләләрне дә үзлегеннән өйрәнеп-белеп барырга тырыша ул.* В.Нуруллин. *Пифагор теоремасын исбат ит.* К.Кәримов

**ТЕОРЕ́ТИК** I *с.* 1) Теориягә бәйләнешле; теориягә нигезләнгән, шуңа караган. *Татар әдәбияты үсешенә шагыйрьнең новаторлык иҗат практикасы гына түгел, ә бәлки теоретик фикерләре дә гаять тирән йогынты ясый.* М.Хәсәнов

2) Практикага карамаган, гамәли булмаган. *Син, Аркаша, Хәйруллинны разведканың теоретик яклары белән таныштыр.* Ә.Айдар. *Атом-төш реакциясе казаннарының ныклыгы Шәүкәт Ибраһимовның теоретик һәм практик эшчәнлегенә дә барып тоташкан булган икән...* Б.Рәхимова

3) Аерым бер фән, сәнгать яки әдәбият өлкәсенең теориясен эшләүгә багышланган. *Тукай турындагы поэзиянең үсеше әдәби-эстетик һәм фәлсәфи алгарыш идеяләре белән бәйләп өйрәнелү сәбәпле, хезмәттә фәлсәфи, әдәби-теоретик материалга да киң урын бирелде.* Н.Гафиятуллина

4) Гадәттә элек табылган белемнәр нигезендә логик фикер белән эш итеп башкарылган яки уйлап табылган. *Хәзер бар да әдәбият: фәнни әдәбият, политик әдәбият, теоретик әдәбият, дуңгыз хакында язган брошюра да – әдәбият!* Х.Сарьян

**ТЕОРЕ́ТИК** II *и. гр.* Нинди дә булса эш, шөгыль һ.б.ш.ның теориясен белүче, теория белән шөгыльләнүче кеше. *Танылган философ, музыка теоретигы һәм композитор Теодор Адорно кайчандыр авангардчылар тарафдары булган.* К.Гыйззәтов. *С.Максуди – татар ренессансы теоретикларыннан берсе, күренеклесе.* М.Хәсәнов

**ТЕО́РИЯ** *и. гр.* 1) Табигать, җәмгыять һәм фикерләү закончалыкларын чагылдырып, тәҗрибәне, иҗтимагый практиканы берләштерә торган тәгълимат. *«Ике буйдак»та А.Расих турыдантуры авыл хуҗалыгында теория белән практиканы бергә бәйләп алып бару мәсьәләсен күтәрә.* А.Расих

2) Аерым эшчәнлек яисә фән өлкәсенә караган идеяләр һәм принциплар җыелмасы (системасы). *Шушы акыл каршында минем гомум кыр теориясен табарга тырышуым, галәмнең дөнья хасил булганчы сингуляр (башлангыч) халәтен эзләвем --- бер тузан бөртегенә дә тормавын аңладым.* И.Әмирхан

3) Фән, сәнгать һәм әдәбиятта осталык мәсьәләләренә караган кагыйдәләр, төп закончалыклар җыелмасы. *Шагыйрьләр арасында ул вакытта әдәбият теориясен иң яхшы белүче дә Шәрәф Мөдәррис булгандыр.* И.Юзеев. *Э.Гофман музыка нәфасәте теориясен башлап җибәрүчеләрдән була.* К.Гыйззәтов

4) Фән, сәнгать яки әдәбиятның саф логик яктан тикшерелгән нигезләре. *Теория бу, Иван Михайлович, сез әйткәннәр. Аның тормышка туры килеп бетмәве дә мөмкин.* С.Рафиков

5) Нинди дә булса күренешне, фактны фәнни яктан аңлатуга юнәлтелгән принципларны раслый торган фәнни нигезләмәләр тупланмасы. *Шундыйлардан – бөек рус химигы Д.И. Менделеевның химик элементларның периодик системасын ачуы, А.Эйнштейнның нисбилек теориясен исбатлавы һәм бер төркем көчле галимнәрнең атом-төш энергиясен файдалану юлларын табуы...* К.Гыйззәтов

6) *куч. сөйл.* Билгеле бер караш, фикер, концепция. *Моның өлешчә дөресleген инкяр итмәстән, шул ук марксизм-ленинизмның, теория буларак, кешелек тарихының милли азатлык көрәшеннән гыйбарәт булуын да кире какмавын әйтергә кирәк.* Ф.Галимуллин

**ТЕО́РИЯЧЕ** *и.* Теоретик; аерым бер теорияне яклаучы кеше. *Галимҗан Ибраһимовны әдәбилек, тел-әдәбият теориячесе, җәмәгать-совет эшчесе булу якларыннан карап, бу өлкәләрдә аның күп хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.* Г.Нигъмәти

**ТЕП-** Кайбер сыйфатлар белән килеп, аларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Менә бу аланда әүмәкләшүчеләр дә – теп-тере бүре балалары.* А.Хәсәнов. *Ерымнан алда кылыч йөзе кебек теп-текә ур һәм... тагын ерым.* В.Имамов

**ТЕПЛИ́ЦА** *и. рус* Суыкка чыдам булмаган үсемлекләрне суык якларда яки, гомумән, үсемлекләрне салкын вакытларда да үстерү өчен ясалган махсус бүлмә яки корылма. *Исәп итсәк, зур гына теплица төзергә дә мөмкин.* В.Имамов. *Әйе, ачу шешe тишелә кайчак: усалрак хатыннар, кызып китсәләр, җаен туры китереп, теплицадамы, басудамы, телләшеп, кирәкләрен бирәләр авыл түрәләренең.* Д.Булатова

**ТЕПЛОВОЗ** *и. рус* Эчке янулы двигательле локомотив. *Менә тепловоз белән алдагы вагон кул кысыштылар,*

*бу бәхетле очрашуга калган вагоннар да шаулап-гөрләп сәлам бирделәр, кузгалып, кыймшанып уяндылар.* А.Гыйләҗев. *Борылмада тепловозның төтене күренде.* Н.Әхмәдиев

**ТЕПЛОХОД** *и. рус* Эчке янулы двигательле судно. *Икешәр-өчәр палубалы зур теплоходлар, олы дәрәҗәләрен саклап, әкрен генә кузгалалар.* Г.Әпсәләмов. *Бер дә көтмәгәндә, теплоходыбызны кара болыт булып сыерчыклар сарды.* А.Хәсәнов

**ТЕПЛУ́ШКА** *с. рус* Кешеләрне йөртү өчен дә файдаланыла алган, тимер мич белән җылытыла торган товар вагоны. *Кайсыдыр, аны култыклап, теплушкага алып китте.* А.Алиш. *Кызгылт сары теплушка эченә кереп капчыкларны сәкегә куюга, хәрби тормыш башланды.* М.Мәһдиев

**ТЕРАПЕВТ** *и. гр.* Терапия өлкәсендәге белгеч-табиб. *Белемем буенча мин – фельдшер, ягъни мин – терапевт, хирург, невропатолог, күз-колак-борын авырулары белгече.* Н.Фәттах. *Ул я хирург, я акушер-гинеколог, сирәгрәге – терапевт буласым килә дияр.* М.Маликова

**ТЕРАПИ́Я** *и. гр.* 1) Нинди дә булса авыруларны хирургия катнашыннан башка төрле ысуллар белән дәвалау системасы. *Мәсәлән, фибринолитик ферментлар һәм гепарин белән комплекслы терапия куллану ярдәмендә кан оешуын бетерергә мөмкин булачак.* Г.Гомәр

2) Медицинаның эчке авыруларны һәм аларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган тармагы. *Әмма терапия бүлегенә баргач, Маһирә ханымны очрата алмады, ул каядыр киткән иде.* Г.Әпсәләмов

**ТЕРӘ** *кис. сөйл. Әнә*, *менә* алмашлыклары белән янәшә килеп, аларга гаҗәпләнү төсмере биреп һәм шул алмашлыклар янында әйтелеп, аларга ышаныч төсмере өсти. *– Менә терә! – дип, Мирхәйдәр абзый ни әйтергә белми шешәгә карый.* Ә.Фәйзи. *Әнә терә, кызың нишләп йөри, чишмә башында җегетләр белән әүмәкләшеп, җаулыгын җыртып кайткан.* Ш.Маннур

**ТЕРӘВЕЧ** *и.* Терәп кую өчен ясалган махсус нәрсә. *Уелып төшмәсен өчен, алга хәрәкәт иткән саен, терәвеч белән терәтеп барырга туры килер әле өстәвенә.* Ә.Әминев

**ТЕРӘВЕЧЛӘ́Ү** *ф.* Терәвеч салу; терәвеч кую

**Терәвечләп кую** Тиз арада яки алдан терәвечләү; терәвечле итү

**Терәвечләп тору** Әле, хәзер яки вакытлыча терәвечләү

**ТЕРӘГЕЧ** *и.* Нәрсәне дә булса терәтеп, терәп тора торган нәрсә. *Ул, арткы утыргычның арка терәгечен тишеп чыгып, кузов калаена эләгеп калган иде.* Ә.Сафиуллин

**ТЕРӘК** I *и.* **1**. 1) *к.* **терәү** II. *Күпергә килеп кергәндә, аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты, куллары талды, арбасын туктатты да таза кулы белән күпер терәгенә ябышты һәм бар көченә терәккә тартылды.* М.Хәбибуллин

2) Нинди дә булса авырлыкка каршы куелган җайланма. *Ул чакларда авыл араларында бастырык юанлыгы гына усак баганалар сузылган булса, хәзер алар урынына көчле тимер аяклы терәкләр утыра*. Г.Галиев

3) Терәлергә яраклы нәрсә. *Рушад ике кулы белән ике як киртәгә тотынды, терәк булды*. М.Мәһдиев. *Ярулла аягына терәк тапты һәм сыңар кулы белән күпер читенә ябышты.* М.Хәбибуллин

4) Урындык, диван кебекләрнең аркасы; терәлгеч. *Солтан, урындык терәгенә таянып, башын ия, йөрәген тота, һаман да хәлсез елмая.* М.Мәһдиев. *Кәгазьләр актарып утырган баш бухгалтер Кәримулла да, өстәл читендә нидер язып торган экономист та, диван терәгенә кунаклаган Равил дә, Харисов шулай диюгә, ни әйтергә белмичәрәк аптырап калдылар.* М.Хәбибуллин

5) *күч.* Ярдәмче, таяныч. *Байлык терәк түгел, берлек терәк.* Мәкаль. *Шәкертләр, без, мәдрәсәбездә милләтебез өчен терәк булырдай галим кешеләр җитешсен дип, акча бирәбез.* Ә.Фәйзи. *Терәк һәм таяныр нокта эзләп, торган саен шул наратка тагы да елыша бара сыман тоелды ул миңа.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Төп таяныч булып хезмәт итә торган. *Аңа ике яктан барырга мөмкин: берсе – өч-дүрт километрлык әйләнеч юлдан, икенчесе – туп-туры, дошманның ике терәк пункты арасыннан.* Г.Әпсәләмов. *Бер ягы белән бина диварына кертеп ясалган дүрткырлы терәк баганалар мәчетнең алгы ягына матурлык өстиләр.* Р.Ахунҗанова

**ТЕРӘК** II *кис. сөйл. к.* **терә**. *Кулың менә терәк, эшең әнә терәк, тотын җәһәтрәк.* Мәкаль

**ТЕРӘКӘ** *кис. сөйл. к.* **терә**. *Менә терәкә, миндә яшәми кайда яшәсен ул, акчасы булмагач...* С.Поварисов

**ТЕРӘКЛЕ** *с.* 1) Терәге булган. *Чарлак сүзе үзе дүрт терәкле манараны аңлаткан.* И.Хуҗин

2) Артлы. *Кышын алай иркенләп, терәкле чаналарга утырып йөрергә вакыты да булмый.* А.Хәсәнов. *Ярый әле терәкле урындыклары бар.* К.Җәмит

3) *күч.* Ярдәме, таянычы булган. *Әмма кыз терәкле иде, мәхәббәтле Кара көчек өрә дип кенә юлыннан тайпылу юк.* Р.Мулланурова. *Көчле иңнәр янында без үзебезне һәрвакыт ныклы терәкле, бәхетле итеп тоярбыз.* Өмет

**ТЕРӘКСЕЗ** *с.* **1.** 1) Терәк куелмаган, терәге булмаган. *Өрлексез өй булмас, терәксез тирмә булмас. Каян табарга өрлекне, каян табарга терәкне!* Н.Фәттах

2) Арткы ягында, аркасында терәге булмаган, артсыз. *Алар беренче очрашудагы урында, терәксез эскәмиядә утырганда, Фәрхунә, сөмсере коелып: – Август беткәндә генә күрешәчәкбез икән, – диде.* М.Хуҗин

3) *күч.* Ярдәм күрсәтер кешесе булмаган, ярдәмчесез, таянычсыз. *Шыр хәерче, бер терәксез килеш син әле япа-ялгыз көе дә күтәрәмгә калган ат кебексең.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Терәк куймаган килеш, терәге булмый торып. *Салиха апа аны озатып калды, поезд күздән югалуга, терәксез калган колмак сабагыдай сыгылып төште.* М.Маликова

2) Ярдәмсез, таяныр кешесе булмаган килеш. *Мөхәммәт Гәрәй үтерелгәннән соң, Сәхиб Гәрәй тәмам терәксез кала.* М.Хәбибуллин. *Хафизә Камиловна да кызын терәксез калдырырга теләүчеләрдән түгел иде.* Ф.Яхин

**ТЕРӘКСЕЗЛЕК** *и.* Терәк, ярдәмче, таяныч булмау

**ТЕРӘКЧЕ** *и.* 1) Шахтада терәкләр куючы эшче

2) *к.* **терәк** I (*5 мәгъ.*). *Инде син дә, угылым, атаңның рухын рәнҗетмә, ислам диненең терәкчесе бул.* Казан утлары

**ТЕРӘЛГЕЧ** *и. диал.* Терәлү өчен билгеләнгән, шул максат белән ясалган нәрсә. *Шунлыктан ул еврей картның йокы арасында маңгае эскәмия терәлгеченә бәрелү белән тиз-тиз генә чукынып алуы Мохтарга кызык тоела иде.* Ш.Камал. *Мәрьям таң ягына караган эскәмиядә, уңга бераз янтаеп, терәлгечкә таянып утыра.* М.Хуҗин

**ТЕРӘЛГЕЧЛЕ** *с.* Терәлгече булган. *Биек капка төбендә теге замандагы, малайның хәтеренә сеңеп калган ярык тагарак юк иде, анда энесе артлы-терәлгечле эскәмия ясап куйган.* М.Хуҗин

**ТЕРӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **терәү**. *Ул [түбәсез өй] ишелгән, ул бүселгән һәм терәлгән артлары.* Н.Исәнбәт. *Кичке чәй вакытында баласын бик әйбәт итеп, яратып сыйлаганнан соң, әни кеше аның янына терәлеп үк утырды да, сүзен зурларча җитди итеп, туптуры итеп әйтте.* Ә.Баян

2) Берәр нәрсәгә сөялеп басу, утыру, тору. *Карт плита янына терәлгән, идәнгә карап, нидер уйлый иде.* Ш.Камал. *Һашимов һаман да стенага терәлеп басып торган Гөлфинур ягына борылды.* А.Вергазов

3) Нәрсәгә дә булса тиеп, орынып тору. *Ахрысы, бу таулар күккә терәлгәндер, дип уйладым.* Г.Әпсәләмов. *Ишектән бөгелеп кергән, башы түшәмгә терәлгән төнге кунакны абайлагач, шау-гөр килгән табын сүрелә төште ---.* Л.Зөлкарнәй

4) Бик якында булу, чиктәш булып тору. *Урман аңа терәлеп кенә түгел, эченә үк кереп тора.* Ә.Еники. *Тик аланның тауга барып терәлгән читендә бердәнбер киртә бар: бер төптән биш тармаклы каен үсеп чыккан.* Г.Әпсәләмов. *Авыз эченнән генә укынаукына, урам башыннан дүртенче, зур бакчасы елга ярына барып терәлгән, җил капкалы, яңарак кына үргән яшел читәнле йорт янында тукталды.* З.Зәйнуллин

5) Ахырына яки берәр җиргә барып җитү, килеп тукталу. *Надир, чигенәчигенә, аркасы белән ташка килеп терәлде.* Р.Сәгъди. *--- бер өч чакрым кыр юлыннан үткәч, Утицкий курганына барып терәлдек.* В.Ильясов

6) Төелү, тыгылу, бөялү. *Үлем бугазына терәлгән кешегә ничек сугасың, ди!* Н.Гыйматдинова. *--- нидер әйтергә маташты Сәбилә, ләкин тамак төбенә килеп терәлгән төер ирек бирмәде.* Р.Вәлиев

7) Кайда да булса тоткарлану, киртәкомачауга туры килеп тукталып калу. *Гариза кантон җир бүлегенә терәлеп, җавапсыз ята.* М.Әмир

8) Кемгә, нәрсәгә дә булса юнәлтеп туры төзәү, төбәү. *Якынлаша палач баш очына, Һәм күкрәккә мылтык терәлә.* Р.Миңнуллин. *Һава тревогасыннан соң шофёр кабина ишеген ачса, аның күкрәгенә пистолет терәлә.* Кызыл таң

9) *күч.* Нинди дә булса кыенлыкка, комачауга очрау. *Җәмгыятебез, кешелек дөньясында гаять зур фән-техника прогрессы булуга карамастан, шәхес тәрбияләү өлкәсендә хәл ителмәслек мәсьәләгә килеп терәлде.* Җ.Фазлыев. *Ә менә җәдитчелек юлы белән киткәч, урысча уку-сөйләшүгә барып терәлдек.* Б.Рәхимова

10) *күч.* Текәлеп, төбәп карау. *Ике күзгә каршы дүрт күз терәлгән хәлдә, байтак тынлык.* М.Фәйзи. *Күзләр күзгә терәлде. Илсурның йөрәге колак төбенә үк килеп тибәргә тотынды.* М.Яһудин

11) *күч.* Нәрсәгә дә булса мөнәсәбәтле, бәйле булу. *Үземә терәлгән бөтен ил хезмәтен үтәп килдем.* М.Галәү. *Зираттан таш ташу игелекле эш түгел шул. Гөнаһлы эш. Тик... Бер тәвәккәлләгәч, эшләмичә дә булмый. Чөнки мунча шуңа килеп терәлгән...* Г.Гыйльманов

12) *күч.* Тик тору, тоткарлану; четерекле мәсьәләгә килеп җитү. *Бөтен нәрсә акчага терәлгән дәвердә кемнедер гаепләп тә булмыйдыр.* М.Кәбиров

13) *күч.* Якынлашу, вакыты җитеп килү; вакыт бик аз калу. *Кышның вакыты бик чамалы калды, Яз терәлеп тора артына.* В.Ильясов

◊ **Терәлеп калу** *к.* **терәлеп тору**. *Эш инде хәзер Дәүләтханга гына терәлеп калды.* А.Хәлим. **Терәлеп кату** *к.* **терәлеп тору**. *Я, кибәк баш, ни терәлеп каттың?* А.Гыйләҗев. *Тегесенең үз киресе кире, бер урында терәлгән дә каткан.* Р.Вәлиев. **Терәлеп тору** 1) Бер урында хәрәкәтсез басып тору; 2) Хәрәкәт, гамәл кирәк булганда, эндәшмичә яки кымшанмыйча бер урында тик тору. *Барам, барам! [ди], ә үзе һаман терәлеп тора.* Г.Камал

**Терәлә бару** Акрынлап тагын да терәлү. *Әмма зур өмет баглаган яңа матдәләрне, басым-температураны «биетеп», төрле режимнарда тикшерүләр куандырмады. Көймә комга терәлә барды.* Р.Хисмәтуллин

**Терәлә башлау** Терәлергә тотыну. *Көймәң комга терәлә башласа, соң дип тормыйсың тагын.* Т.Әйди

**Терәлә бирү** Бернигә карамастан терәлү. *Ул [Асылгәрәй] утырган урындыкка аркасы белән терәлә биреп, Рушанияга эшләпәсе астыннан гына карап утыра.* З.Кадыйрова

**Терәлә төшү** Бераз терәлү. *Минем җилкәмә терәлә төшеп, бөтен гәүдәсе белән миңа таба борылды.* Гали Рәхим

**Терәлә язу** Аздан гына терәлми калу. *Хәерле юлга чыкканмын икән: ярты сәгать тә үтмәде, эзләгән каеныма терәлә язып туктап калдым.* Н.Әхмәдиев

**Терәлеп алу** Азга гына терәлү

**Терәлеп тору** Әле, хәзер терәлү; һәрвакыт терәлгән хәлдә булу. *[Ләзизә карчык:] Терәлеп торган күршең Ләзизәнең кече капкасы сөйрәлеп ачыла.* М.Хуҗин

**ТЕРӘТКЕ** *и.* Терәтү өчен махсус ясалмаган, ләкин терәтә торган нәрсә (махсус ясалган булса, «терәве» диләр). *Капка терәткесе*

**ТЕРӘТКЕЧ** *и.* 1) Терәлгеч; таяну өчен билгеләнгән нәрсә. *Бер аягын икенчесе өстенә куеп, терәткечсез урындыкта утырган сыра сатучы егет битараф кына сигарет төтәтә иде.* Л.Лерон

2) Терәү, терәк. *Габдуллаҗан шундук номер әзерләде: әллә каян гына каеш табып, биленә буды, шул каешка кылыч итеп ишек терәткеч озын таяк такты, бер ягына алтатар урынына чи бәрәңге кыстырды да, ишекнең теге ягына чыгып, яңадан полисмен булып керде.* Р.Батулла

**ТЕРӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **терәү**. *И-и-и ул мәктәптән ишеге тышкы яктан көрәк сабы белән терәтелгән ялгыз өйгә кайтып керүләр!* В.Нуриев

2) Ава төшкән, тотрыклылыгын югалткан нәрсәне терәп, ныгытып кую. *Өйнең елга ягына карап торган сыңар тәрәзәсе дә томаланып, ярык ишкәк белән терәтеп куелган.* М.Хәсәнов. *Капка эчтән терәтеп куелганга, капка башыннан сикереп төште, тәрәзәгә килде.* З.Кадыйрова

**Терәтә башлау** Терәтергә тотыну

**Терәтеп кую** Терәтелгән хәлгә китерү. *Юк кына бит, минсиңайтим, чыдамый гына терәтеп куйган чыбык, шартлап сына.* Н.Әхмәдиев. *Якты төшсенгәдер инде, Нурислам абзый иске тактадан ясалган ишекне ачып, аны шунда торган бер тимер белән терәтеп куйды.* С.Поварисов

**Терәтеп тору** Әле, хәзер терәтү; гел, дәвамлы терәткән булу. *Агачларының ябалдашы әйтерсең күкне терәтеп тора.* К.Җәмит

**ТЕРӘ́Ү** I *ф.* 1) Сөяү, сөялдерү; берәр нәрсәгә авыштырыбрак орындыру. *Ул келәгә басмады, биек коймага терәп, аякларын җиргә күмеп ясалган эскәмиягә утырды.* М.Хуҗин. *Мәхмүт тә аркасын каенга терәде дә үзалдына сөйләнеп утыра бирде.* З.Кадыйрова

2) Аву, ишелү, ачылу һ.б.ш.ның ихтималы булган әйберне, тотрыклы хәлдә тоту өчен, берәр нәрсә белән ныгыту, өстәмә тотрык бирү. *Басарый җилкәсе белән ишекне терәп тора.* Т.Гыйззәт

3) Якын итеп, ара калдырмый орындырып салу, ялгау (биналар, каралтылар тур.). *Быел җәй үк, мунчага терәп, гараж кебек бер корылма саласы бар.* Җ.Юныс

4) Нәрсәне дә булса, бик якын китереп, нәрсәгәдер тидерү, орындыру. *Ул --- егетнең болай да язгы күк гөмбәзе шикелле яшькелт, җылаксып торган йөзен үзенең танавына китереп терәде.* А.Хәлим

5) Нәрсәне дә булса берәр өслеккә ныклап урнаштыру, шуңа таяу. *Сафа абый үзе, кузла баскычына аягын терәп, кәләпүшен басыбрак киде.* Г.Бәширов. *Ярым караңгы залга кереп, асты әйләнмәле урындыкларга урнашып, терсәкләрне терәп куюга, һәркем рәхәткә чумды.* М.Мәһдиев

6) Кемне дә булса куркытып, янап, шуңа төбәп якынайту (йодрык, корал һ.б.ш. тур.). *Ул егылгач, авызына пистолет терәделәр.* Г.Әпсәләмов. *Бәләбәйдән кайткан чакта, Кушйөрәк тау үрендә юлбасарлар, урап алып, муенга сәнәк терәгәч, мине үлем тырнагыннан синең атаң гына йолып калды.* В.Имамов

7) Карашны юнәлтү, текәү, туры итеп карау. *Аның бөтенләй гаҗизләнгән хәлдә күзләрен терәп катып калуыннан Гөлфинур үз-үзен белештермичә туарылып китте.* А.Вергазов

**Терәп кую** Терәлгән хәлгә китерү. *Сафа аны ябышкан тирестән арындырды да, ишегалдына алып чыгып, яшелчә бакчасы коймасына терәп куйды.* Г.Исхакова

**Терәп тору** Әле, хәзер терәү; озак вакыт, дәвамлы терәү. *Селкенергә дә ирек бирмичә, шул ук сихри көч дүрт ягыннан да терәп тора кебек иде.* Г.Гыйльманов

**ТЕРӘҮ** II *и.* 1) Тотрыклылыгы бозылган берәр нәрсәне билгеле бер хәлдә тоту, ныгыту, беркетү өчен кулланыла торган бүрәнә, борыс һ.б.ш.; терәк, таяу. *Күршең бай булса, капкаңа терәү сал.* Мәкаль. *Ишеккә терәү салыгыз, бастырык!* А.Гыйләҗев. *Солдаткага сиздермичә генә бәпкә киштәсенә ике терәү куйды да киштәне дә өзде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Ярдәмче, таяныч, терәк. *Чүгендер уташып яки, ашлык тапшырганда, машиналар биреп ярдәм итү кебек эшләр белән булышу ярый. Ләкин шефлык моның белән генә чикләнсә, ул әллә ни зур терәү булмас, дуслар.* С.Рафиков

◊ **Терәве имән** Коры холыклы, туры сүзле. *Аның [Миңнулланың] терәве имән, терәсә каты тери ул.* И.Гази

**ТЕРӘҮЛЕ** *с.* Терәве булган; терәтелгән, терәү белән ныгытылган. *Йорт-каралты да коелып төшкән: өч-дүрт тапкыр сипләнгән, салам түбәле, кырык терәүле, бүген-иртәгә ишелеп төшәм дип тора.* М.Хәсәнов. *Анысының капкасы ук эчке яктан терәүле булып чыкты.* Г.Әдһәм

**ТЕРӘҮЛЕК** *и.* **1.** 1) Терәүгә ярый, терәү буларак кулланыла торган әйбер (агач, таш һ.б.ш.). *Ялкау ир мич терәүлегенә ярар.* Мәкаль. *Әнә әрдәнә-әрдәнә бүрәнәләр өелгән, шпаллар, терәүлекләр...* Х.Хәйруллин

2) Терәү, терәк, таяу. *Капкага терәүлек кую*

**2.** *с. мәгъ.* Терәүгә ярарлык, шуңа дип билгеләнгән. *Терәүлек агач*

**ТЕРГЕЗҮ** *ф.* 1) Үлгәннәргә яки үлә башлаганнарга яңадан җан кертү, терелтү, тере итү. *Мондый ышаныч хәтта иң көчсезгә дә көч-куәт бирергә, хәтта үлене дә тергезеп аягына бастырырга мөмкин сыман иде.* Н.Фәттах

2) Савыктыру, сәламәтләндерү, аякка бастыру. *Сихерчеләр: – Бу авырудан тергезү өчен, Шаһмараны күргән кеше кирәк, – диләр.* Әкият

3) Тәмам таркалу хәлендә булган хуҗалык объектларын төзек хәлгә китерү. *Шул ук басуларны яңадан әйләнешкә кертү, җимерелгән фермаларны тергезүне үз кулына алырлык инициативалы кешеләр кирәк.* Кызыл таң. *Илне җимерекләрдән тергезү өчен, күп көч салдылар.* Безнең гәҗит

4) Гомумән нинди дә булса корылманы төзү, салу. *Сине ташламам, келәт хәтле бер йорт тергезүгә кайтып алырмын.* В.Имамов. *Колхоз өй тергезергә булышмас микән?* Н.Гыйматдинова

5) *күч.* Рухи көч бирү, күтәрелеш, дәрт өстәү. *Бу эш, бер яктан, безне тергезеп һәм гайрәтләндереп җибәрде.* Ф.Әмирхан. *Тергезәм үлгән йөрәкне ант итеп.* Ш.Бабич

6) *күч.* Кимегән, сүлпәнләнгән, бетү дәрәҗәсендә булган нинди дә булса процессны, күренешне яңадан җанландырып, көчәйтеп җибәрү. *Кабаттан тергезеләчәк Көл өеменнән Минем һәм синең йөрәгең, Күптәннән беләм.* Ф.Яхин. *Соңгы елларда әлеге йола яңадан*

*тергезелеп, халык, милләт дәрәҗәсендәге, яшь буынны тәрбияләү әһәмиятендәге эшкә әверелде.* Шәһри Казан

7) *күч.* Аерым бер тәртип урнаштыру, нәрсә дә булса оештыру. *Дөньяга дуслык, татулык тергезик.* Н.Исәнбәт

**Тергезә башлау** Тергезергә керешү. *Мин башлаган эшләрне, ичмаса, угылларым-оныкларым дәвам итсә, мин тергезә башлаган ил-йорт нигезен алар исән-сау көенчә саклый алса иде!..* В.Имамов. *Гөлсылу чишмәдән су алып менгәндә, егет, вак-төяк коры ботакларны оештырып, учак тергезә башлый.* Р.Гаязетдин

**Тергезеп җибәрү** Кинәт тергезү; тергезергә керешү. *Габделбәр ике-өч җирдә учак тергезеп җибәрде.* А.Хәсәнов

**Тергезеп кую** Тергезелгән хәлгә китерү. *Тәрәзә йөзлекләрен, коймакапканы үзебезнең милли бизәкләр белән бизәп, матур йорт тергезеп куйганнар.* Казан утлары

**Тергезеп тору** Тергезү процессында булу; әледән-әле тергезү. *Мәңгелек ут шикелле мәңгелек яшәү ялкынын алар тергезеп тора.* Ш.Галиев

**Тергезеп яту** Тергезү процессында булу. *Хәйдәр туган, белгәнегезчә, бик изге эшкә тотынды: бакча тергезеп ята.* В.Имамов

**ТЕРЕ** *с.* **1**. 1) Үлмәгән, җанлы булган, исән (кеше яки хайван тур.). *Шуннан соң гына Миңнулла үзенең тege чокырдагы мәетләр арасында түгел, ә тере кешеләр арасында икәнлеген аңлады.* В.Нуруллин. *Менә синең моңарчы тере төлке күргәнең юк иде.* Н.Хәсәнов

2) Организм буларак яши торган, тереклек иткән. *Тере күзәнәкләрнең гади бүленү юлы белән үрчү ысулы да ташланмаган, бактерияләр генә түгел, катлаулы организмдагы күзәнәкләр дә шул юл белән үрчиләр.* А.Тимергалин

3) Шиңмәгән, сулмаган (үсемлек тур.); ясалма булмаган. *Такталар алдында тере чәчкәләр.* Т.Әйди

4) Нәкъ үзе булган, чын, асыл хәлендәге (сирәк очратыла торган кеше һ.б.ш. тур.). *Тере кулак күргәнем юк, ди идең, Гаяз, менә шушы инде ул, күр.* М.Әмир. *Әлбәттә, тере депутатны үз гомерендә беренче тапкыр күргән авылның хәлен аңларга мөмкин иде.* Ф.Җамалетдинова

5) *күч.* Җанлы, хәрәкәтчән, йөгерек. *[Мәхмүт] Өстәвенә, бик кызыклы итеп сөйли; шул сөйләм рәвешеннән чыгып, аның бик тере, хәрәкәтчән, күзәтүчән, мавыгучан малай икәнлеген күреп алабыз.* И.Гази. *Әнә минем Габделхәмитнең малае. Яңача тәрбияләр. Шулкадәр тере бала. Һич кенә дә тик тормый.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Актив табигатьле, үткен, җитез, чая характерлы. *Тынгысыз, тере малай көн буе диярлек елга буенда, тау араларында югалып йөри.* Ә.Еники. *Бала чакта мин дә бик тере, чая бала идем, авыруның нәрсә икәнлеген дә белмәдем.* Ф.Бәйрәмова

7) *күч.* Изрәрлек дәрәҗәдә пешеп җитмәгән; бик үк пешеп җитмәгән (ярма һ.б.ш. тур.). *Менә дигән бутка булып чыкты. Тозы да чак. Ярмасы да тере түгел.* Г.Толымбай. *Аны ашый башлагач: – Дөгесе тере, ите аз, майга лычкылдаткансың, – дип, савытын этеп җибәрде, пылау өстәлгә чәчелде.* Ф.Садриев

8) *күч.* Әле янып көйрәп яткан, уты сүнеп бетмәгән (күмер, куз тур). *Тере күмер – тиле күмер [янгын чыгара].* Мәкаль. *Сулышымнан ут бөркелә: Тере күмер – уртларымда. Эссе!* И.Киньябулатов

9) *күч.* Күзгә ташланып торган, ярылып яткан, ап-ачык. *Санасаң санап бетмәслек ялгыз эти-әниләр. Кичә ил тоткасы булган – Бүген тере ятимнәр.* Җыр. *Илдар өчен Мирсәй бер тере хәсрәт кенә булды.* Г.Гобәй

**2.** *и. мәгъ.* Җанлы зат, тереклек иясе. *Үлем үрләмәсен терегә. Тере тәгәрәтсен үлемне.* Ф.Кәрим. *Тәбәнәк, болаңгыр күктә ягымлы кояш күренде; тирәякны яктыга, куанычка күмеп, җирдәге барлык терегә күз кысып, шаярып, кайнар укларын яудырды.* Н.Фәттах

**3.** *рәв. мәгъ.* Исән килеш, җанны саклап. *Авыр үлем белән көрәшәбез. Исәп әле тере калырга.* А.Алиш

◊ **Тере архив** *к.* **тере тарих**. *Күпләр аны «тере архив» диләр.* Сәхнә. **Тере килеш тунау** *к.* **терeләй тунау**. **Тере көйгә тунау** *к.* **терeләй тунау**. **Тере көч** Хәрби техникадан аермалы буларак, сугышчылар, солдатлар һ.б.ш. гаскәри состав. *Курск дугасында без аны уратып алып, кораллы тере көчен юк итә алмадык.* З.Зәйнуллин. **Тере коридор** Ике якка тезелеп баскан кешеләр хасил иткән аралык. *Үлем мәйданына алып керә торган зур бушлыкның як-ягында, тере коридор булып, икеөч метр саен кораллы эсэсчы тора.* М.Хәсәнов. **Тере почмак** Мәктәптә һ.б.ш.да гадәттә вак йорт хайваннары асрала торган урын: кечкенә зоопарк. *Тере почмак булдырып, анда аквариум балыкларын, җитез кәлтә кебек хайваннарны тәрбияләргә өйрәнделәр.* Туган як. **Тере су** *к.* **тере суы**. *Шулай да, Нургаязның бабасы элекке елларда моны үзенчә гөманлап аңлата торган булган, диләр. Имеш, бу – тере су, тирә-юньдәге калын урманның җаны.* Р.Мөхәммәдиев. **Тере суы** *миф.* Үлгәннәрне терелтә, аларга җан кертә, авыруларны савыктыра, аякка бастыра һәм, гомумән, көч-куәт арттыра торган су. *Надан кулыннан су эчмә, тере суы булса да.* Мәкаль. *Иртәгесен җир өстенә барып баскач, Нәфисә, бодаеның тере суы бөркегәндәй күпереп китүен күреп, тагын куанды.* Г.Бәширов. **Тере тарих** Озак яшәп, күпне күргән, бик күпне белүче һәм күргәнбелгәннәрен бик теләп сөйли торган кеше. *Әле күптән түгел генә сыман Кузкәй авылының мәдәният йорты сәхнәсендә без авылыбызның тере тарихы, авылдашларының горурлыгы Галимҗан Шакирҗан улы Вәлиевның 90 яшен гөрләшеп бәйрәм иткән идек.* Якты юл. **Тере тутый тоту** Көтелгәннән, өмет ителгәннән дә артыграк уңышка ирешү турында. *Тимер чынлап та, тере тутый тоткан шикелле булды.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Тере чәчәк** Кәгазь, тукыма һ.б.ш. эшләнгән бизәкләрдән аермалы буларак, табигый чәчәк. *Гаҗәп, дип уйлады Тукай, кыш азагында тере чәчәкләрне кайдан ала икән бу туташ?* Р.Батулла. *Өстәл уртасындагы матур вазада – тере чәчәкләр.* Т.Әйди. **Терeләй тунау** 1) Кемгә дә булса зур начарлык эшләү, бик авыр

хәлгә кую; физик яки рухи газапларга дучар итү. *Ул чагында әнисе Ихсанбайны терелай тунаячак.* Т.Гарипова; 2) Матди байлыгын, акчасын һ.б.ш. көчләп тартып алу, талау, күп итеп түләттерү

**ТЕРЕК** *с. сөйл.* **1.** *к.* **тере 1.** (*1–3 мәгъ.*). *Бел наданнар төркемен үлек диеп, Үлсә галим – бел аны терек диеп.* Г.Утыз Имәни. *Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм!* Г.Тукай

**2.** *и. мәгъ. к.* **тере 2.** *Дулкыннар салават әйтәләр: Үлгәннәргә данлык! Терекләргә иркенлек!* Г.Коләхмәтов

**ТЕРЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Терелү, савыгу, сәламәтләнү

2) *күч.* Җанланып, рухланып, активлашып китү. *--- хөкүмәтебезнең шифалы, саф җилләр кебек әледән-әле исеп торган, һәрнәрсәне терекләндергән бөек карарлары безнең Кенәлене читләтеп кенә уздылармы әллә?* М.Хәсәнов

3) *күч.* Ныгып, тормыш хәлләре әйбәтләнеп китү; тернәкләнү

**Терекләнә башлау** Терекләнергә тотыну

**Терекләнеп бетү** Тәмам, бик нык терекләнү

**Терекләнеп килү** Күптәннән бирле терекләнү. *Үлмәс җанга бер сәбәп дигәндәй, начылый-начылый гына терекләнеп килдек, туганай.* Мәйдан

**Терекләнеп китү** Соңгы арада терекләнү. *Сәхнә сәнгатенең шулай терекләнеп китүе әдәбиятның үзенчәлекле жанры булган драматургиянең тизлек белән үсүен булдырды.* Татар әдәбияты

**ТЕРЕКЛЕК** *и.* 1) Җанлы булу; терелек. *Күп заманнар буенча ачлыктан кыркылып бөрешкән эченә кинәт ашау ярамадымы, әллә, аның тәнендә тереклек акрынлап бетә-бетә, шулай үлем җиткән чагына туры килделәрме – моны белә алмадылар, белергә дә теләмәделәр.* Г.Ибраһимов

2) Тере организм булу сыйфаты. *Лотос орлыклары --- торф катлавында ике йөз илле ел буе тереклекләрен саклап калалар һәм шытым бирәләр.* Робинзон эзләреннән

3) Исән чак, дөньялык. *Тереклектә сыйлашмасаң, үлгәннән соң елашма.* Мәкаль. *Кич сибелгән Айның нурларында Олы җиһан тулы серләр бар, Тереклектә һәркемнең үз җаны, һәрбер җанда олы хәят бар.* А.Нәҗми

4) Гомер итү, яшәеш; яшәү. *Җирнең йөзе матурлана кояш белә, Барчабызның тереклеге шуннан килә.* М.Гафури. *Хәлбуки илләр, халыклар кебек, елгалар үзләре дә бозыла, тереклек чыганагы булган чиста сулар зарарлы матдәләр белән агулана.* С.Сабиров

5) Яшәргә, үсәргә омтылыш, яшәү дәрте; яшәү көче, яшәү стимулы. *Ләкин бу күзләрдә тереклекнең актык чаткысы да сүнгән иде инде.* Г.Ибраһимов

6) Җан иясе, тере булган һәр нәрсә. *Бу вакытта ике фәрештә кояшны алтын чылбырлар белән Каф тавы артыннан өстерәп чыгардылар, дөнья нурга манчылды, урамнарда тереклек кайный башлады.* Ф.Әмирхан. *--- диңгезнең үлгән балыкларын һәм башка тереклекләрен ашарга ярый.* Н.Ибраһимов

7) *күч.* Җанланып китү, җанлылык, хәрәкәт. *--- яз җиле кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык һәм тынычлык белән исә дә дөньяга яңару һәм яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы һәм җансыз нәрсәләрне үзләренә бер төрле тереклектә коендыра иде.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Тормыш, көн итү, көнкүреш. *Шәригать аларга ирләргә биргән хөрриятне вә тереклек эшләрен алдан күрүдә ирләрнекенә тиң ясаса, хиҗаб аларны эшкә керешүдән тыя вә хәбескә саладыр.* Г.Бубый

◊ **Тереклек иясе** *к.* **җан иясе**. *Җирдәге тереклек ияләренең күбесен ашыгыбрак әрәмтамакка чыгармыйсыңмы?* А.Хәсәнов. *Кешенең һәм барча тереклек ияләренең табигый сайланыш юлы белән барлыкка килүен исбат иткән дарвинизм фәне Аллаһны инкяр итми, киресенчә, ул Аның бөеклеген генә күрсәтә, чөнки болар барысы да илаһи программа буенча тормышка ашырыла бит.* А.Тимергалин. **Тереклек суы** *к.* **тере суы**. *Аның адымнарын, тавышын ишетү, аның кулыннан ризык кабу, күздәге һәм кулдагы бәйләвечне алыштырганда, аның бармаклары җылысын тою үлеп барган җанга, әкияттәге тереклек суы кебек, шифа бирә иде.* М.Маликова

**ТЕРЕКЛЕ́К ИТҮ** *ф.* 1) Җанлы, тере булу, яшәү, яшәү процессында булу. *Тереклек итүнең төп шарты булып матдәләр алмашы исәпләнә.* А.Тимергалин. *Ароморфоз --- тереклек эшчәнлегенең интенсивлыгын арттыра торган, ләкин тереклек итүнең кискен чикләнгән шартларына тар җайлашу гына булмаган эволюцион үзгәрешләрдән гыйбарәт.* Гомуми биология

2) Үсүне дәвам итү, шиңеп, корып, яшәүдән туктамау (үсемлекләр тур.). *Берән-сәрән генә утырган нарат үсентеләре һаман бирешмәгәннәр әле, тереклек итеп азапланалар.* А.Гыйләҗев

3) Гомер итү, көн итү, тормыш алып бару. *Элекке теләнче Мохтар хәзер инде Мохтар әфәнде Хәмитов булып, имам булган Хисаметдингә үз акчасына мәдрәсә салдырды вә мәдрәсә шәкертләренә кесәсеннән, тереклек итәр өчен, акча билгеләде.* М.Акъегет. *Хакыйкатькә генә хезмәт итәргә тиешле затларны бүксә хакына эшләтергә азапланган заманда тереклек иткән булабыз.* Н.Сафина

**ТЕРЕКЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **тереклек итү**. *Ул Шәмсегаянны ияртте дә авыл читенә, япа-ялгыздан ничарадан бичара тереклек кылып азапланган ятим карчык Таифә йортына барып урнашты.* А.Гыйләҗев. *Әсмабикәгә ир биреп, «үзе аерылган» исеме күтәреп тереклек кылсынмы?!* Н.Гыйматдинова

**ТЕРЕКЛЕКЛЕ** *с.* Тереклек көче булган, яшәргә сәләтле. *Габделбасыйрның бу яңа хәле ләззәтле вә тереклекле дә түгел.* Ф.Әмирхан

**ТЕРЕКӨМЕШ** *и.* Гадәттә сыекча хәлендә була торган ялтыравык ак авыр металл. *Аның урынына Ык суының терекөмештәй елтыр бөртекле тамчылары чиләкләргә алындылар да, сиптергечкә салынып, яңгыр тамчыларыдай, яшелчәләрнең сусавын бастылар.* А.Алиш. *Буага яисә коега бер-ике генә бөртек терекөмеш салып кара әле менә син!* А.Гыйләҗев

**ТЕРЕ́К-ТЕРЕК** *иярт.* **1.** Аякларны тиз-тиз алмаштырып, вак-вак атлап юырту, йөгерү, бик тиз бару рәвешен

белдерә. *Карт тирәкнең, агайларның Язмышлары бер үк кебек. Шуңа, ахры, агайлар да Теркелдиләр терек-терек.* Ч.Мусин

**2.** *рәв. мәгъ.* Вак, җиңел хәрәкәтләр белән, ашыкмыйча (юырту, йөгерү һ.б.ш.). *Терек-терек киттек тагын.* М.Вәли-Барҗалы. *Ялкау алаша кебек гомерең буе терек-терек барганчы, сабан туе аргамагы сыман беренче килеп, янып егылуың яхшырак түгелме?* Р.Вәлиев

**ТЕРЕЛӘЙ** *рәв.* 1) Тере, исән, җанлы килеш. *– Әгәр дә мәгәр, – диде ул, – бертуган энесенең кайтуыннан файдаланып, өебез эчендәге шомлы хәлләрне, Сабитның явызлыгын, кансызлыгын, азганлыгын, хатынын терелэй ләхеткә тыгуын түкми-чәчми ачып салсам?..* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Кызганусыз, аяусыз, җәлләмичә. *Терелэй тунадылар бит агачны.* З.Мәхмүди. *Синдәй хаинга үлемнең дә хәтәрен табарбыз --- я зәңгәрсу залда юкка чыгарырбыз, яисә тандыр-кабабта терелэй кыздырырбыз.* Р.Мирхәйдәров

◊ **Терелэй суюу** *к.* **терелэй тунау**. *Мине терелэй суясың киләме әллә.* Р.Сәгъди. *Үтерде, терелэй суйды. Мин әле аны сәрхушка санаган идем, ә ул китте акыл өйрәтеп, китте...* Ф.Яхин. **Терелэй ашау** Бик каты җәзалау, интектерү яки әрләү, тиргәү һ.б.ш. *Тукта, министрга хәбәр итим әле, югыйсә терелэй ашый ул мине.* Р.Сәгъди. *И анысына куандым: өйдә калсам, Төркиядә юккабарга туздырган акчалар өчен хатын терелэй ашый иде бит үземне.* Н.Әхмәдиев. **Терелэй йоту** Зур кыенлык тудыру; кискен каршы чыгу. *Югарыда әйтелгән «алтын кагыйдә»нең кирәклеген безнең халыкка әйтеп карыйк әле – терелэй йотачаклар.* Кызыл таң. **Терелэй тунау** 1) Кайтарырга яки түләргә тиешле акчаны тулысынча биреп бетермичә, күпмедер өлешен тотып калу яки нәрсәдер өчен бик кыйбат түләтү. *Хуҗа безне терелэй тунаучылар дип саный, гәрчә без аңардан күпме каерганнарын белми дә калабыз.* Казан утлары; 2) Кансыз рәвештә бик нык җәзалау; кирәкне бирү. *Сизеп торам, Шәйхетдин абый, терелэй тунаячаклар безне.* М.Хуҗин

**ТЕРЕЛӘНҮ** 1) *сир.* Терелү, сәламәтләнү, савыгу. *Казанда укый башлагач, терелэнеп, үсеп тә китте.* Безнең гәҗит

2) Тере (*2 мәгъ.*) булып китү, җитезләнү, җанлану. *– Мәсәлән, аяк киемен урлаган өчен күп бирәләрме? – диде Мидхәт, терелэнеп.* З.Хәким

**Терелэнеп китү** Акрынлап терелэнү; соңгы арада терелэнү. *Вәсим терелэнеп китте: – Минемчә, монда сәбәп әтиемнең язмышына бәйләнмәгән.* З.Хәким

**ТЕРЕЛӘТӘ** *рәв. к.* **терелэй**. *Әмма ул елны иген дә, печән дә уңмагач, шуның өстенә, колхозчыга сыер тоту артык мәшәкать ул, дип тә әйтеп торганда, тирә-як авыллар сыерларын йә суеп сатарга, яки дәүләткә терелэтә тапшырырга керештеләр.* В.Нуруллин. *Кодрәтеннән килсә, терелэтә ашар иде.* М.Хәсәнов

**ТЕРЕЛЕК** *и.* 1) Тере булу хәле; җанлылык, исәнлек. *Җырларда табигать картиналары бөтен терелеге, нечкәлекләре белән бирелгән.* Г.Нигъмәти. *Бөтен терелеге, җаны күзләрендә генә иде микәнни соң аның?* Ф.Садриев

2) Активлык, җанлылык, җитезлек. *Берлектә – терелек.* Мәкаль. *Ул үзенең гаять терелеге, үткенлеге, янып торган сирәк матурлыгы белән барысыннан да аерылып тора.* Ф.Бәйрәмова

3) Җитезлек, уяулык, сизгерлек. *Мин беренче очратканда ук, ул инде студент, иптәш кызларыннан терелеге, үзен аурупача иркен тотуы белән аерылып тора иде.* Т.Әйди

**ТЕРЕЛТКЕЧ** *с.* **1.** Терелтә торган, шифалы. *Көймә эченә терелткеч һава йөгерде.* Г.Әпсәләмов. *Әинде яңа темага керешү, әсәр язу аның өчен шатлык, сөенеч чыганагы гына түгел, ә яшәү рәвеше, терелткеч дару да иде.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* Терелтә торган, шифалы нәрсә. *Ул [Габдулла Тукай] уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хастаны.* Ш.Бабич

**ТЕРЕЛТҮ** *ф.* 1) Үлгәннәргә яки үлә башлаганнарга яңадан җан кертү, тергезү, тере итү. *Апаны кабердән казып чыгарулары бар бит. Аны барыбер терелтеп булмый, тыныч йокласын, мескенкәй.* Г.Әпсәләмов. *Ул күзсезләрне күзле иткән, аксакны йөрткән, саннарын төгәл иткән, үлекләрне терелткән.* Ф.Яхин

2) Авыруны савыктыру, сәламәтләндерү, аякка бастыру. *Чыкмаган җанда өмет бар, дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар ---.* Ә.Еники

3) *күч.* Кире кайтару, торгызу, яңарту. *Ә күргәнебезчә, Булатта спектакльне терелтү өчен мөмкинлекләр аз түгел.* Безнең гәҗит

**Терелтә башлау** Терелтергә тотыну. *КБМҮдә балаларны «көнгерә» алымы буенча карап терелтә башладылар.* Мәдәни җомга

**Терелтеп җибәрү** Кинәт терелтү. *Апрельнең җепшек кичендә, мәҗлестән кайтышлый, көтелмәгән бу кыска сөйләшүнең, әйтәсе дә түгел, минем үземә тәэсире көчле булды: күптән инде сүнгән өмитне ул яңадан терелтеп җибәрде...* Ә.Еники

**Терелтеп тору** Әледән-әле терелтү. *Сине, яшьлек елларыбызның, бәхетле чорыбызның иң якын, аерып алгысыз кешесе буларак, без хәтеребездә гел терелтеп торабыз, янәшәбездә тоябыз.* Ф.Садриев

**ТЕРЕЛҮ** *ф.* 1) Үлгәннән соң яки үлем чигенә җиткәннән соң тагын яши башлау. *– Кабернең ташын нык бастырган булсагыз ярый, казакның бер сүзе бар: яман адәм яңадан терелә икән, – диде [Биремҗан].* Г.Ибраһимов

2) Савыгу, сәламәтләнү, манту. *Нәфисә терелә, диегез, юатыгыз үзен.* Г.Кутуй. *Акчадан котылгач, ул чак кына җиңеләеп, чирдән терелгән кеше сыман, хәлсез аякларын авыр сөйрәп, баскычтан менеп китте.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Җанлану, хәрәкәткә килү. *Абыем мине күрде, Яныма чабып килде. Баскычка менеп баскач, Кулына ачкыч алгач, Нидер эшләгән итте, – Сәгатем терелеп китте.* Ж.Тәрҗеман

4) *күч.* Яңадан кабатлану, кайту. *Янган яшьлек, Үткән мәхәббәтләр – Алар мәңге миндә терелмәс.* Һ.Такташ. *Китеп барган җәйнең Озын керфекләре арасыннан Җылы күз яше тамды – Терелде күңелем гөлләре.* Ф.Яхин

**Терелә башлау** Терелүгә табан бару. *Алар өчен чын проблемалар терелә башлагач туа.* А.Хәсәнов

**Терелә төшү** Берникадәр терелү. *Салих терелә төште. Ул хәзер аксап кына йөри.* Г.Исхакый

**Терелеп бетү** Тәмам терелү. *Нәфисә дә терелеп бетә алмады.* Г.Гыйльманов

**Терелеп җитү** Ахыргача терелү. *Ул бит әле һаман да тәмам терелеп җитмәгән, тиз генә эшкә чыга алмаячак.* Н.Әхмәдиев

**Терелеп килү** Соңгы арада терелә башлау. *Баласының тамагында дифтерия түгел, үлекле ангина булган икән, ул инде терелеп килә.* Д.Каюмова

**Терелеп китү** Ниндидер вакыттан, сәбәптән соң терелә башлау. *Әле генә еларга җитешкән ханым кинәт кабынып, терелеп китте.* З.Хөснияр

**ТЕРЕ́ЧӘ** *с. диал. к.* **терчә**. *Түгәрәк йөзле, теречә күзле җитез малай, әле нибары биш яшьтә генә булса да, кәгазь-карандаш ярата.* Т.Әйди

**ТЕРКӘВЕЧ** *и.* Кәгазь кисәге һ.б.ш. нәрсәне теркәп, кадап, беркетеп куя торган юан башлы энә яки бөкләнгән тимерчыбык

**ТЕРКӘГЕЧ** *и. грам.* Җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмлә өлешләрен үзара бәйләү өчен кулланыла торган сүз төркеме (мәс., *вә, һәм, ләкин, мәгәр, яки* һ.б.ш.). *Андагы телбизәкләр яки сатира, юмор, киная, ирония кебек стилистик алымнар, шулай ук теркәгечсез, иясез җөмлә төзү чаралары һәм башка бик күп яклар да үзенә игътибар сорый.* Н.Исәнбәт

**ТЕРКӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **теркәү**. *Менә шул эшне тикшерү вакытында, ни хикмәттер, сезнең исемегез теркәлгән бер язу-кәгазь табылды.* З.Бигиев

2) *иск.* Орыну, кушылу, терәлеп тору. *Ачулы һәм кәефсез вакытларында аның [Корбангалинең] иреннәре бергәрәк теркәлә.* Ш.Камал

3) Янәшә яки бер-бер артлы тезелеп тору. *Аның әмерен көтеп, әнә бер җепкә теркәлгәндәй, салмак дулкын өстендә саллар тибрәлә.* М.Әмирханов

4) Бер-берсенә беркетелеп, тезелеп ясалу. *Шпаллардан теркәлгән мунча сыман куышта ул [Ислам] бердәнбер хуҗа булып калды.* Н.Фәттах

5) Бербөтен булып, бер төпкә төпләнү (китап-дәфтәр тур.). *Бу әсәр бергә теркәлгән хатирә дәфтәрләреннән гыйбарәт.* М.Гафури

**Теркәлә бару** Рәттән булган берсе теркәлү. *Кем белән очрашкан, көрешкән, кемнәрдә кунакта булган – һәммәсе теркәлә бара.* Р.Мөхәммәдиев

**Теркәлә башлау** Теркәлергә керешү. *Ул вакытта балалар аз туган, үлүчеләр күп булган, гаиләләр азрак теркәлә башлаган.* Безнең гәҗит

**Теркәлеп бару** *к.* **теркәлә бару**. *Төрле оешмалардан килгән рәсми кәгазьләр дә, аерым кешеләрдән алынган үтенечләр һәм аларга Чеканың үз җаваплары да шулай ук теркәлеп барырга тиеш иде.* Т.Әйди

**Теркәлеп кую** Тиз генә яки алдан теркәлү. *Балалар ишетәләрме моны, юкмы, аңлыйлармы, юкмы – бу теләкдогалар инде күкләргә киткән, тәкъдир китапларына теркәлеп куелган иде.* Ф.Бәйрәмова

**ТЕРКӘ́Ү** *ф.* 1) Нинди дә булса әйберләрне янәшә беркетү; үзара терәтеп кую. *Бер-берсенә теркәп салынган вак-вак корылмалар зур ямаулыкны хәтерләтә.* Р.Зарипов. *Такталарны теркәп тезү*

2) Аерым кисәкләрне билгеле бер тәртип белән җыю. *Әле дә хәтеремдә: әтием үз куллары белән ясаган агач сәкедә, әнием үз куллары белән теркәп теккән корама юрган астында без тезелешеп йоклыйбыз.* Ф.Шәрәфетдинова

3) Кенәгә, папка һ.б.ш.га берәр яңа документ, нинди дә булса язу өстәп беркетеп кую. *Инспектор тартмадагы язуларны зур кызыксыну белән янә бер тапкыр карап чыкты да беркетмәгә теркәп куйды.* Ш.Шәйдуллин

4) Нинди дә булса вакыйганы тикшерү эшенең документлары җыентыгына шул эшкә мөнәсәбәтле берәр әйберне кушу. *Фарукҗан Галимҗан абыйсы сейфтан алып биргән унатарны алтын остасы асылташлар тикшергән шикелле күздән кичерде, соңра фаҗига урыныннан табылган дип беркетмәгә теркәлгән пуляны да искиткеч игътибар белән әйләндергәләп бакты.* Т.Әйди

5) Нинди дә булса фактны, фикерне язып кую. *Китапсыз гына юрап; балаларыңның санын, оныкларыңның яшен искә төшереп; өнең белән буталган төшеңне гамәл дәфтәреңә теркәп; оялтмыйча һич туктамаслар.* К.Кәримов. *Наталья Комарова изге теләкләрен Мактаулы кунаклар китабына теркәде.* Мәдәни җомга

6) Нинди дә булса рәсми оешмада юридик яктан рәсмиләштерү, регистрация ясау һ.б.ш. *Машиналарны тикшерәсе, катнашучыларны теркисе бар.* Татарстан яшьләре

7) Әзер текстка башка бер әсәр өзеге кертү; җыентыкка башка бер авторныкы булган яисә башкачарак бер әсәрне өстәп кую. *Пьесаларга иллюстрация рәвешендә язылган музыкаларның күпчелеге --- әсәргә теркәп куелган оригиналь җырлардан гыйбарәт.* М.Җәлил

**Теркәп бару** Эзлекле рәвештә барысын да теркәү. *Берсе – начар, икенчесе яхшы гамәлләрне теркәп бара.* З.Мәхмүди. *Шундый бер җыелышта Гайсәр Галие Таҗиның чыгышын протоколга теркәп барган.* К.Кәримов

**Теркәп кую** Тиз генә яки алдан ук теркәү. *Асылов Мәүлиха апа әйткәннәрне теркәп куйды, кул куйдырды.* А.Гыйләҗев. *Чөнки авыл Советы секретаре туу турында таныклыкларына шулай теркәп куйган.* Т.Нәҗмиев

**Теркәп узу** Эш, сүз уңаеннан теркәү. *Ул [Сөләйманов] иң элек ферма мөдиренең бүгенге җаваплы җыелышка бик өстән генә хәзерләнеп килүен зур бер гаеп итеп теркәп узды.* Ә.Еники

**Терки бару** Бер-бер артлы барысын да теркәү. *Шәмси мулла аларны прошениегә килештереп терки барды.* М.Галәү

**Терки башлау** Теркәргә тотыну. *Иргәш авылдашларыннан кемнең кайсы байга никадәр бурычы булганын, шуны түләргә күпме мал китүен терки башлады.* Т.Әйди

**ТЕРКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Терек-терек итеп атлау, йөрү, тәгәрәү. *Вагоннар теркелдәп китеп баралар, кинәт Сәкинә тавышы яңгырый.* А.Гыйләҗев. *Фәһимә башта җәяү теркелдәде.* Д.Каюмова

**Теркелди башлау** Теркелдәргә тотыну. *Туры бия, Фәтхелислам агай дилбегә кагуга, тагын үз көенә әкрен генә теркелди башлады.* Ф.Абдуллин

**Теркелди бирү** Бернигә карамый теркелдәү. *Үз юллары юл, пристань ягына теркелди бирделәр.* Ф.Сафин

**ТЕРКЕШ** *и. тар.* Ук савыты

**ТЕРЛЕК** *и.* Йорт хайваны, мал (башлыча тояклы мал). *Шуңа күрә терлекләр дә аны яратмаганнар һәм бервакыт йоклап яткан Мачинны таптап измәкче булганнар, ди.* А.Тимергалин. *Шулай ук аларның сарык, кәҗә ише терлекләре дә бар.* А.Нәҗми

◊ **Терлек асты** Яңа салам, торф һ.б.ш. җәелеп, даими тазартылып торырга тиешле абзар идәне. *Терлек астын коры тоту да әһәмиятле.* Т.Әйди. *Чыгарылган торф ягулык, ашлама сыйфатында һәм терлек астына җәю өчен кулланыла.* Биология

**ТЕРЛЕКЛЕК** *с.* Терлеккә дип билгеләнгән, терлек асрау өчен, терлекләргә кирәкле булган. *Күршеләр терлеклек печән әзерләгәндә, Фазылҗан гына авыз ачып калмыймы?* Ф.Хөсни

**ТЕРЛЕ́К ӨЕ** *и.* 1) Кышкы суыкларда туган бәрән, колын, бозау ише терлек-туар балаларын вакытлыча асрау өчен җылытыла торган абзар. *Миңгайшә апа капкадан кергәндә, хатын терлек өендә апара соса иде.* Н.Гыйматдинова

2) Мал караучылар, терлек асраучылар, көтүчеләр кереп ял итү, җылыну һ.б.ш. өчен салынган махсус йорт

**ТЕРЛЕК-ТУАР** *җый. и.* Ит-сөт һ.б.ш. продукция алу өчен асрала торган һәртөрле йорт хайваннары, малтуар. *Тыкрык очыннан терлек-туар тавышлары ишетеп тышка чыкты һәм, абзарын ачып, ике сарыгын, ике кәҗәсен көтүгә куып керде дә чәен куйды.* А.Хәлим

**ТЕРЛЕКЧЕ** *и.* Мал-туар, терлек асрау эшендә эшләүче кеше. *Аннары терлекчеләр йортында эш кызды.* А.Вергазов. *Фәрите фермага терлекче булып урнашты, Фәридә шунда сыерлар саварга алынды.* К.Кара

**ТЕРЛЕКЧЕЛЕК** *и.* Мал-туар, терлек асрау эше; авыл хуҗалыгының шуның белән шөгыльләнә торган тармагы. *XV гасыр – XVI гасырның беренче яртысында мордвалар хуҗалыгында игенчелек, терлекчелек, кошчылык, умартачылык, һөнәрчелек һәм сәүдә зур роль уйнаган.* Б.Хәмидуллин

**ТЕ́РМА** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы Римда гимнастик күнегүләр, әңгәмәләр өчен бүлмәләре булган җәмәгать мунчасы

2) *геол.* 20 градустан артык җылылыктагы җир асты сулары; җылы сулы чишмә

**ТЕРМАЛЬ** *с.* Термалар (*2 мәгъ.*) белән бәйле, шуңа караган. *Термаль чыганаклардагы суның кайнарлыгы 54 градуска җитә.* Сөембикә

**ТЕ́РМИК** *с.* 1) Югары температура, җылылык белән бәйле

2) *тех.* Техникада җылылык энергиясен кулланып эшли торган. *Бигрәк тә цехларда эш күп, термик чыныктыру мичләре җитешми.* Н.Хәсәнов

3) *мед.* Югары температура тәэсире белән барлыкка килгән. *Термик пешү*

**ТЕ́РМИН** *и. лат.* Фән, техника, сәнгать өлкәсендә, иҗтимагый-сәяси әдәбиятта аерым бер төшенчәне белдерә торган махсус атама, сүз яки сүз тезмәсе. *«Иҗат методы» термины совет әдәбият фәнендә узган гасырның 30 нчы елларында гына кулланышка кертелгән.* А.Әхмәдуллин. *Җөмләдән, «вакытлы матбугат» дигән термин-дагы «вакытлы» сүзен дә, безнеңчә, мотлак үзгәртергә кирәк.* Х.Сарьян

**ТЕРМИНАЛ** *и. лат.* 1) *тех.* Берәр системаның тышкы тирәлек белән элемтәсе булган соңгы өлеше

2) Пассажирларны транспортка утырту-төшерү, йөкләрне төяү-бушату өчен билгеләнгән урын (тимер юл вокзалында яки автовокзалда – перрон, су транспорты өчен – причал, аэропортта – махсус билгеләнгән урын). *Алтысыннан уникенче майга кадәр Казан аэропорты ветераннарга икенче номерлы терминалның VIP залында хезмәт күрсәтәчәк.* Мәдәни җомга

3) Компьютерда мәгълүматны кертүалу өчен билгеләнгән җайланма. *Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы оперативниклары Казандагы Р.Зорге урамында «Империя» дигән уен автоматлары салонынннан 15 уен аппараты, 18 компьютер терминалы ала.* Безнең гәҗит

4) Физик затлар финанс операцияләре, чиратка язылу һ.б.ш. гамәлләр башкару өчен билгеләнгән махсус җайланма. *Араларында терминалның эре купюраларны тимер акчаларга вакла-выннан да зарланучылар булган.* Ватаным Татарстан

**ТЕРМИНИТ** *и. гр.* Гадәттә лаборатория шартларында югары температура тәэмин итү өчен кулланыла торган коры спирт. *Терминит (коры спирт) ярдәме белән кабызылган учак тирәли утырган геологлар юеш киемнәрен киптерәләр.* Ә.Айдар

**ТЕ́РМИНЛАШТЫРУ** *ф.* Сүзгә термин статусы бирү, термин сыйфатына кертү, термин сыйфатына күчерү. *Рус телендәге колесница һәм двуколка арбаларын «сугыш арбасы» һәм «ике тәгәрле арба» яки «бер күчәрле арба» дип терминлаштырып булыр иде.* А.Тимергалин. *Семасиология тармагында тикшерүләр алып барган галимнәр әлеге компонентны денотат дип терминлаштыра.* И.Бәширова

**Терминлаштыра бару** Акрынлап терминлаштыру

**Терминлаштырып бетерү** Тәмам терминлаштыру

**ТЕ́РМИНЛАШУ** *ф.* Терминга әверелү. *Диалекталь сүзләр дә әдәби телгә яңа мәгънәдә кереп терминлашып китәргә мөмкиннәр.* Фән һәм тел

**ТЕРМИНОЛО́ГИЯ** *и. лат.* Билгеле тармакка караган терминнар системасы. *Татарча терминология исә яралгы хәлендә генә булып, терминнар, гадәттә, гарәби, фарси яки интернациональ алынмалар рәвешендә яшәп килә.* А.Тимергалин. *Бездә әдәби-нәзари терминология яхшы ук эшләнгән.* А.Әхмәдуллин

**ТЕРМИСТ** *и. лат.* Металлны термик ысул белән эшкәртүче белгеч. *Гаилә ишәйгәч, Урал вагон заводына күбрәк акчалы эшкә күчә һәм термист (металларны термик юл белән эшкәртү) һөнәрен үзләштереп, танк броняларын чыныктыру остасына әйләнә.* Ватаным Татарстан

**ТЕРМИТ** I *и. гр.* **1.** Алюминийның яки магнийның башка металл окись-

лары белән янганда бик югары температура чыгара торган порошоксыман катнашмасы. *Һәрбер яңа бөртек – илгә куәт. Дошманнарның йөрәгенә термит, фугас.* Ә.Ерикәй

**2.** *с. мәгъ.* 1) Прессланган термиттан торган. *Финнар аны яна торган термит шашкалар өстенә ташлаганнар, өстән бүрәнә белән бастырып куйганнар.* Г.Әпсәләмов

2) Эченә термит (*1 мәгъ.*) тутырылган. *Иптәшләренә Ислам, 1941 елда термит снаряды утында пешеп, күз нервларына зыян килүдән, дип аңлатты бу күз яшьләрен.* М.Хәмитов

**ТЕРМИТ** II *и. гр.* Турыканатлылар семьялыгыннан җылы якларда җиргә оя корып, зур колонияләр хасил итеп яши торган кырмыскага охшаш бөҗәк; ак кырмыска. *Термитлар корыган агач кәүсәләрен һәм коелган яфракларны бертуктаусыз таркатып торалар, ә вакланган калдыкларны гөмбәләр һәм бактерияләр эшкәртеп бетерә.* Башлангыч география курсы

**ТЕ́РМО-** *гр.* Кушма сүзләрнең «термик» дигән мәгънәне белдерә торган беренче компоненты (мәс., *термопластика, термодинамика, термоэлектрон, термохимия*)

**ТЕРМО́ГРАФ** *и. гр.* Һава, су һ.б.ш.ның температура үзгәрешен эзлекле рәвештә теркәп бара торган әсбап, җайланма

**ТЕРМО́МЕТР** *и. гр.* Температураны үлчи торган әсбап, җайланма. *Термометрны кул җитәрлек урында гына тотты һәрвакыт.* Ф.Баттал. *Комендант термометрны күзәтеп кенә тора.* М.Мәһдиев

**ТЕРМОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* 1) Температура үлчәү ысуллары һәм алымнары җыелмасы

2) *физ.* Физиканың температураны үлчәү ысулларын, алымнарын өйрәнә торган тармагы

**ТЕРМОРЕГУЛЯ́ТОР** *и. гр.-рус* Автомат рәвештә температураны билгели һәм кирәкле дәрәҗәдә тота торган әсбап, җайланма. *– Карап, күзәтеп торырга тәрәзә ясадым, вентилятор, электр лампочкалары, терморегулятор куйдым, – дип сөйли Фәрдис абый.* А.Сабирова. *Ә температура режимы терморегулятор ярдәмендә тотыла.* Кызыл таң

**ТЕ́РМОС** *и. гр.* Эченә салынган нәрсәне даими температурада саклый торган махсус савыт. *Иң зур термоска гөлҗимеш төнәтмәсе ясап куйды.* К.Тимбикова. *Таныш хатыннарның термостан булары чыгып торган кайнар чәй агызганнарын күреп алып, Нурия алар янында гына тукталырга булды.* К.Кара

**ТЕРМОСТАТ** *и. гр.* 1) Эчендә даими температура саклана торган махсус лаборатория җайланмасы

2) *тех.* Берәр системада даими температураны тәэмин итә торган прибор. *Радиатор, термостат кебек әйберләрне дә ишеткәнең юк инде синең?* В.Имамов

**ТЕРМОТЕРАПИ́Я** *и. гр. мед.* Җылылык, югары температура белән дәвалау ысуллары һәм медицинаның шуларны өйрәнә торган тармагы

**ТЕРМОФИЛ** *и. гр.* Температура югары булган тирәлектә яшәргә күнеккән организм

**ТЕРМОФИЛЬ** *с.* Термофилларга хас, асылы шул булган. *Элек ипине әчеп утырган камырдан пешерсәләр, бүген күпчелек очракта термофиль чүпрә кулланалар икән.* Татарстан яшьләре

**ТЕРМОФОБ** *и. гр.* Температура күтәрелүгә түзә алмый торган организм. *Гөмбәләр арасында термофоблар бар*

**ТЕРМОЭЛЕМЕНТ** *и. гр.* Җылылык тәэсирендә ток хасил итә торган техник җайланма

**ТЕРНӘК** *и.* 1) Таган аягы

2) *күч.* Яклаучы, химаяче; таяныч, ярдәмче. *Тернәгең дә булсын, тырнагың да булсын.* Әйтем

**ТЕРНӘКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* 1) Авыру, ачлык һ.б.ш. сәбәпләр аркасында хәлсезләнгәннән соң көч керү, аякка басу, ныгып китү, терелү. *Әнисе операциядән соң тернәкләнмәде, гомер көзенә дә кермәгән килеш, авыру ирен калдырып, мәңгелек йортка китеп барды.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Төзекләнү, рәткә килү, җанлану, алга китү, активлашу. *Урнашкач, бәләкәй генә тернәкләнгәч, әтиәниләренә посылка салыр!* А.Гыйләҗев. *Болай әйтергә татар мәктәпләренең, инде бөтенләй бетте дигәндә, соңгы елларда яңадән тернәкләнеп эшли башлаулары мөмкинлек бирә сыман.* Б.Рәхимова

**Тернәкләнә бару** Торган саен ныграк тернәкләнү. *Җәен онтылып торган хисләр-хыяллар кабат тернәкләнә бара.* Ф.Яхин

**Тернәкләнә башлау** Тернәкләнүгә табан бару. *Бүгенге көндә иң беренче чиратта дәүләтчелегебезне булдыру – мөһим бурычларның берсе. Хәер, бу юнәлештә нидер эшләнә башлады инде. Тернәкләнә башладык кебек.* Р.Вәлиев. *Сеңлем Гөлкәй дә күзгә күренеп тернәкләнә башлады.* А.Хәсәнов

**Тернәкләнә төшү** Бераз тернәкләнү. *Больницадан соң, әз генә тернәкләнә төшкәч, аңа өч бүлмәле бик шәп квартира бирделәр.* Г.Ахунов

**Тернәкләнеп алу** Берникадәр вакытка гына тернәкләнү. *90 нчы елларда – суверенитет игълан ителгән елларда – телебез дә күзгә күренеп тернәкләнеп алды.* Р.Фәйзуллин

**Тернәкләнеп бетү** Тәмам тернәкләнү. *Җырчы әле дә, аякларына басып, тамашачы алдында концерт бирә алуына сөенеп туя алмый. Ә бит ул һаман да тернәкләнеп бетмәгән.* Сәхнә

**Тернәкләнеп җитү** *к.* **тернәкләнеп бетү**. *Тик бер Әкрәм кари гына тернәкләнеп җитә алмый иде.* М.Галәү

**Тернәкләнеп килү** Соңгы арада акрынлап тернәкләнү. *Шулай да Азат әкренләп аякка басуын, тернәкләнеп килүен, ягъни фани дөнья һәм иртәгесе көн белән кызыксына башлавын сизә.* А.Тимергалин

**Тернәкләнеп китү** Билгеле моменттан алып тернәкләнү. *Гайнекамал карчыкның улы Мирзанур комбайнда эшли башлады да тиз ара тернәкләнеп китте: өен сипләп яңартты, лапаскура тергезде, Түбән авылдан фельдшер кыз Сәкинәне килен итеп төшерде.* А.Гыйләҗев

**ТЕРНӘКЛЕ** *с.* 1) Тернәге яки тернәкләре булган. *Өч тернәкле – таймас таган, дүрт тернәкле – аумас таган.* Мәкаль

2) Терәге, ярдәмчесе, тернәге булган. *Тернәкле адәм түрәне кол итәр.* Мәкаль

3) Хәле ныклы, хәлле. – *Әллә биргән вәгъдәң бармы? – дип төпченде Сәхипҗамал апа, Гөлшәһидәнең мондый тернәкле егетләрне кире боруын бер дә яратмыйча.* Г.Әпсәләмов

**ТЕРНӘКЧЕЛ** *с.* Һәрвакыт терәк, таяныч булырга әзер торган, ярдәмчел. *Тернәкчел кеше ат тизәген алтын итә.* Мәкаль. *Мондый мәкальләрнең бик күп булуы татар халкының чынлап та бик тырыш, бик тернәкчел, хезмәт сөючән булуын, эш белән куәтле булуын күрсәтә торган әһәмиятле моментлар.* Н.Исәнбәт

**ТЕРПЕ** *и.* Кыргыч игәү; эре сырлы игәү. *Терпе өстенә тукмак.* Әйтем

**ТЕРРАКО́ТА** *и. ит.* 1) Яндырылган сары яки кызыл балчык; шул балчыктан ясалып, глазурь белән ялтыратылмаган эшләнмәләр (сын, савыт-саба һ.б.ш.). *Бу хакта сөйли торган борынгы сурәтләр һәм терракота сыннар сакланып калган* Н.Фәттах

2) Яндырылган кызыл балчык төсе. *Күп очракта сипкелле хатын-кызларның макияж төсләре – алтын, терракота, зәйтүн, көрән, хаки.* Сөембикә

**ТЕРРА́РИЙ** *и. лат.* Төрле вак бөҗәкләр, елан-чаян, кәлтәләр һ.б.ш.ны асрый торган тартма, бүлмә, витрина һ.б.ш.

**ТЕРРА́РИУМ** *и. лат. к.* **террарий**. *Элемтәгә кергәч, егетнең күңеле йомшарган булып чыкты: – Террариум белән ун тараканны бер мең сумга гына сатып җибәрәм, – диде.* Шәһри Казан

**ТЕРРА́СА** *и. фр.* 1) Зур өйгә терәтеп салынган түбәле киң болдыр яки коридор рәвешендәге корылма. *Улының гадәтен яхшы белгәнгә, чәйне террасага хәзерләтте.* К.Тинчурин. *Өсләренә кигән бер генә кат күлмәкнең изүләре ачык булуга карамый, террасада утырган ике кеше эсселектән газап чигәләр иде.* Гали Рәхим

2) Тау битендә табигый яки махсус ясалган баскычлардан торган горизонталь яисә бераз сөзәк мәйдан. *Иртәдән алып кичкә кадәр туктаусыз эштә алар: тау итәкләренә террасалар ясап, аны дөге, бодай, кукуруз һәм яшелчә үстерү өчен җайлаштыралар.* Н.Хәкимуллин

**ТЕРРАСАЛАП** *рәв.* 1) Террасалы итеп. *Түрдә террасалап салынган зур йорт күренә.* Т.Гыйззәт

2) Террасалар рәвешендә. *Кояш якка караган тау битләвендә бакчалар, андагы түтәлләр баскыч-баскыч итеп, террасалап эшләнгән.* А.Тимергалин

**ТЕРРА́САЛАУ** *ф.* Тау битләренә төрле террасалар (*2 мәгъ.*) ясау. *Карарда билгеләнгәнчә, --- янтыкларны террасалау, эрозиягә каршы корылмалар кору күздә тотыла.* Социалистик Татарстан

**Террасалап кую** Тиз арада яки алдан террасалу

**ТЕРРА́САЛЫ** *с.* 1) Террасасы булган. *Башта ачык вагон ишегеннән зәңгәр буяулы, террасалы җиңел йортлар, нарат урманы эчендәге җыйнак дачалар күренеп барды, аннары поезд киң кырларга чыкты.* Г.Әпсәләмов

2) Террасалар рәвешендәге, киртләчле, рельефлы

**ТЕРРА́СКА** *и. иск. к.* **терраса** (*1 мәгъ.*). *Шәһәрнең крахмаллы күлмәкләрен салып ташлап, Анна Васильевна хәзерләп куйган җәйге җиңел күлмәкне киенеп, аякка чәпедәвек киеп, терраскада хәзерләнгән чәй янына килеп утыргач кына, чыннан да, үзен үзе дачада итеп хис итте.* Г.Исхакый

**ТЕРРЕНКУР** *и. фр. махс.* Ком, туфрак өстендә йөреп дәвалану өчен, озынлыгы һәм вакыты чикләнгән махсус маршрут. *Чөнки Кисловодскида терренкур нигезендә дәвалану киң җәелгән.* Казан утлары

**ТЕРРИКОН** *и. фр. махс.* Җир астын казыганда, конус формасын хасил итеп җыелган ташландык токымнар, җир, балчык яки шлак өеме. *Күмер шахталары, терриконнар арасында рәсем ясарга оста куллы Рита яши...* А.Гыйләҗев

**ТЕРРИТОРИАЛЬ** *с.* 1) Билгеле территориягә караган, шуңа бәйләнешле. *Янәсе, ул территориаль мохтарият турында сүз йөртәсе урынга милли-мәдәни мохтарият белән канәгатьләнеп кала.* С.Максуди

2) Территориягә, табигый яки административ өлкәләргә карап башкарылган. *Галим инкыйлаб һәм реакция көннәрендә телдә ике агым – төрекчелек һәм татарчылык агымнарының көрәшен билгеләп уза, аларның территориаль чикләрен күрсәтә ---.* Т.Гыйлаҗев

**ТЕРРИТО́РИЯ** *и. лат.* 1) Чикләре анык билгеләнгән коры җир өсте мәйданы. *Әмма Оренбург губернасының бөтен территориясендә фетнәдә катнашучы татар, удмурт, мари, башкорт крестьяннарының саны 86 мең 541 кеше белән генә чикләнә алмый.* В.Имамов. *Дежуркадан хәбәр: май заводы территориясендә исерекләр сугыша икән.* З.Мурсиев

2) Шәһәр, өлкә һ.б.ш.ның аерым халыкара кануннарга буйсынган яки үзенчәлекле статусы булган бер өлеше. *Ирекле территория*

**ТЕРРОР** *и. лат.* 1) Сәяси яки сыйнфый көрәшнең барлык ысулларны, хәтта үтерүне кулланган үтә кискен формасы; шундый көрәш алып барылган чор. *Алардагы бу сәләтне 1920–1950 еллар арасындагы вакыт эчендә илдә җәелдерелгән террор сәясәте әкренләп зәгыйфьләндергән.* Ф.Галимуллин

2) Кемгә дә булса үтә кансызлык, аяусызлык; куркыту, янау. *Карагруһлар терроры бөтен җирдә котырынды.* Г.Кашшаф. *Әмма Тукай турында беренче татар пьесасы дөньяга чыкканчы, --- рухи һәм физик террор канат җәйгән иҗтимагый тормышта интеккән татар әдипләренә, галимнәренә зур эш башкарырга, батырлык күрсәтергә, көрәшергә кирәк була.* М.Шәрипов

**ТЕРРОРИЗМ** *и. лат. к.* **террорчылык**

**ТЕРРОРИСТ** *и. лат. к.* **террорчы**. *Террористлар түгелме дип шикләнеп, кемдер поезд начальнигына хәбәр итте, ахры: килеп документларын да тикшереп киттеләр.* Д.Булатова

**ТЕРРОРИ́СТИК** *с.* Террор куллануга бәйләнешле; террор булып торган. *Казанның Химиклар урамында берничә ай элек кенә үткәрелгән махсус операция дини һәм сәяси юнәлештәге төркемнәрнең халыкка һаман да террористик һәм экстремистик җитди куркыныч тудыруын сөйли.* Мәдәни җомга

**ТЕРРОРЛЫК** *и. ялг.* 1) *к.* **террор**. *Америка Хәрби һава көчләренең кечкенә Вьетнамны пыран-заран китереп ташлавы Нью-Йоркта булган тер-*

*рорлык гамәленнән кечкенәмени, Буш әфәнде?* Р.Батулла. *Террорлык актлары илебездә дә, чит илләрдә дә күзәтелә.* Шәһри Казан

2) *к.* **террорчылык**

**ТЕРРОРЧЫ** *и.* Сәяси көрәштә террор сәясәте тарафдары; террор ысулы белән эш итүче; террорда катнашучы. *Һәм үзләренә тагылган террорчылар дигән яланы алып ташларга мөмкинлекләре дә юк.* И.Хуҗин

**ТЕРРОРЧЫЛЫК** *и.* Террор сәясәте һәм гамәле; террор күренешләре. *Террорчылык сәбәпләре аркасында, беренче урынга икътисад чыга.* М.Мәхмүтов. *2010 елның апрелендә Мәскәү метросының «Лубянка» һәм «Мәдәният паркы» станцияләрен тар-мар иткән шартлаудан соң халыкның 33 проценты террорчылыкны җиңеп булмаячагына ышанган.* Ватаным Татарстан

**ТЕРСӘК** *и.* 1) Беләкнең буынланып артка чыгып торган урыны. *Көтүче Гамис чыбыркысын иңенә салса, буй җитмәс бер әкият каһарманына әйләнә, шундый чакта аның иске ботинкасы, терсәк турылары сыпылып уңып беткән зәңгәр күлмәге, ямаулы чалбары да өр-яңа булып күренә иде.* М.Галиев. *Кыз егетнең терсәк тирәсеннән йомшак итеп «умырып тотты».* Р.Гаязетдин

2) Кием җиңенең шул турысы. *Терсәге ямаулы мәктәп күлмәген еламсырап киюемне күреп, олы апам, мудный бит ул, дия иде.* Татарстан яшьләре

3) Бармаклар очыннан алып кулның шул турысына кадәр озынлык; шуңа тиң озынлык үлчәү берәмлеге; зираг. *Тоташ карадан киенгән руханилар исә, үзләренең яңа диннәренә таянып, тәреләрне җиде терсәк буйлык итеп ясаттылар.* М.Хәбибуллин. *Газиз картка бүген бәхет елмайды – иртә таңнан төшкә кадәр бер балык та тота алмаган иде, кайтырга җыенганда гына, терсәк буе кәрәкә эләкте.* Г.Гыйльманов

4) *куч.* Механизм, машина һ.б.ш. җайланмаларда төрле штокларның, валларның бөгелеш урыны. *Сер менә нәрсәдә икән: җиденче узелда аппаратның зур терсәген беркетәләр.* Совет әдәбияты

◊ **Терсәк белән төртеп** Төрле гадел булмаган юллар белән башкаларны узып алга чыгу турында. *Габдулла углы Туфан Миңнуллин – киң офыклы әдип, беркайчан да көндәшләрен терсәк белән төртеп өскә күтәрелмәде ---.* Р.Батулла. **Терсәк заманы** Үз максатыңа ирешү, син дигәнчә булсын өчен, этешеп-төртешеп, башкалар белән санлашмыйча яшәү. *Уңай геройлар әзләмә, таба алмыйсың син аларны, ач күзеңне, тормыш бу, хәзер терсәк заманы: төрткәләп, таптап китмәсәләр – бик рәхмәт.* Д.Булатова. **Терсәкне тешләү** Нык үкенү. *Эшләмәсәң, үкенүдән терсәгеңне тешләрсең.* Г.Камал. *Эш узгач, терсәк тешләргә омтылудан ни файда?* Ф.Яхин. **Терсәкне тешләп булмау** Нинди дә булса гамәл кылганнан соң, үкенеп тә үткәнне кайтара алмауны аңлау. *Эш үткәч, терсәкне тешләп булмый.* Мәкаль

**ТЕРСӘКЛӘ́Ү** *ф.* Терсәк (*3 мәгъ.*) белән үлчәү

**ТЕРСӘКЛӘШҮ** *ф. сир.* Берберсенә терсәк белән тиеп китү, төртеп алу. *Олаучылар серле итеп терсәкләшеп, үзара ымлаштылар.* С.Баттал

**ТЕРСӘКЛЕ** *с. тех.* Төрле күчәрдә урнашкан берничә буыннан торган. *Хәмитнең тракторы двигателен салдырып куйганнар иде. Терсәкле валын кырдырып алып кайтканнар.* В.Гали. *Суга чупылдап барып төшкән чиләк, су белән тулып, чыгырны сөйрәде, коеның терсәкле тимер тоткычы зыр-зыр әйләнеп, коточкыч шау-шу куптарды.* Д.Каюмова

**ТЕРТ** *иярт.* Хәрәкәтнең кинәт, җиңел, тиз үтәлү рәвешен белдерә. *Теге [Бибизөһрә] терт итеп сикереп торды да табын уртасында бушап калган зур агач табакны кинәт кенә күтәреп алды.* Ә.Фәйзи

**ТЕРТӘЮ** *ф. диал.* Кием астыннан тырпаеп беленеп тору. *Фоат дигәннән, тагын бер оятлы итте ул мине – әтисе пинжәтеннән иңбашы тертәеп чыккан малай.* Ф.Хөсни

**Тертәеп тору** Тертәйгән торышта булу. *Тыгыз итле ябь-яшь беләкләр, эчке күлмәгенең челтәре астыннан тулы гына күкрәкләре тертәеп торалар [Сәрвәрнең].* Ф.Хөсни

**ТЕРТЛӘ́Ү** *ф.* Кинәт калтырап кую, дерт итү; сискәнеп китү

**Тертләп китү** Кинәт тертләү. *Һәр суккан саен, Гыйлфанның тәне тертләп куйганы сизелә.* С.Сөләйманова

**Тертләп кую** Бер тапкыр тертләү. *Көтмәгәндә яңгыраган ачы тавыштан Рөстәм тертләп китте.* М.Кәбиров

**ТЕ́РТ-МЕРТ** *иярт.* Кискен хәрәкәтләр белән анда-монда тартылуны, сикергәләүне белдерә. *Шулай булса да әле, чәчен ала башласаң, куркак куян шикелле, терт-мерт итеп, соры күзләрен яшьләндереп, аларны бер ачып, бер йомып, мәлҗерәп утырыр иде.* С.Поварисов. *Яшьләр өчен чит авазлардан әвәләнгән, терт-мерт сикертә торган җыр сыман нәрсәне бүгенге шартларда куып таратып булмыйдыр инде.* Шәһри Казан

**ТЕ́РТ-ТЕРТ** *иярт. к.* **терек-терек**. *Аңа [атка] терт-терт итеп йөгерүче кечкенә йонлач эт ияргән иде.* И.Нуруллин

**ТЕРЦЕТ** *и. ит.* 1) *муз.* Өч тавыш белән башкару өчен язылган вокаль әсәр (җыр, ария); өч башкаручыдан торган ансамбль. *Беренче пәрдәдә терцет (Фәрит, Фатыйма, Разия) өчен шактый материал бар.* М.Җәлил

2) *әд.* Өч юллы строфа. *Әле кайчан гына берьялгызы хөкем сөргән ике юллы куплетларга күрше булып өч юллы куплетлар – терцетлар килә. Аннары мәйданга дүрт юллыклар – катреннар күтәрелә.* Ш.Әхмәдуллин

**ТЕРЧӘ** *с.* Тере, тынгы белмәс, хәрәкәтчән, җитез, һәрвакыт актив булган (гадәттә балалар тур.). *Бала дигәне – дүрт-биш яшьтәге терчә малай: «Әни!» – дип, «кунак кызы»на килеп сарылды.* З.Хөснияр. *Иркәләнү-сөелүдән туймый торган өч яшьлек Бибиҗамал – шомырт кара күзле, ут борчасы шикелле терчә кызы исә – Мостафаның кайгылы-хәсрәтле көннәрендә иң олы юанычы, шатлыгы, куанычы иде.* Ф.Сафин

**ТЕРЧӘЛӘНҮ** *ф.* Терчә булып китү, терчәгә әйләнү

**Терчәләнә төшү** Тагын да терчәләнү

**Терчәләнеп бетү** Бик нык терчәләнү

**Терчәләнеп кую** Кинәт терчәләнү

**ТЕРЧӘЛЕК** *и.* Хәрәкәтчәнлек, җитезлек, терелек. *Шул чем кара күзләре, шул терчәлеге белән дә, сәеррәк киемнәре белән дә башкалардан аерылып тора ул малай.* Р.Төхфәтуллин

**ТЕРЧӘН** *с. диал.* 1) Җитез, йөгерек, хәрәкәтчән (гадәттә, балалар һәм картлар тур.). *Терчән карчык*

2) Бик үткен, чая. *Директор бик терчән кеше булып чыга, ә тегеләр...* Н.Вахитов

**ТЕРЧӘНЛӘНҮ** *ф. диал.* Терчән булып китү, терчәнгә әйләнү

**Терчәнләнә төшү** Бераз терчәнләнү

**Терчәнләнеп бетү** Бик нык терчәнләнү

**Терчәнләнеп кую** Кинәт терчәнләнү

**ТЕРЧӘНЛЕК** *и.* Терчән булу сыйфаты

**ТЕТӘБИКӘ** *и. сөйл.* Тиргәшүчән, әрләшергә яратучан хатын

**ТЕТӘЛӘҮ** *ф.* Бик нык тетү, теткәләп бетерү. *Чәйнәсә бәгъренне ерткычкорт, тетәләп ташласа.* С.Сүнчәләй

**Тетәләп бетерү** Барысын да тетәләү

**Тетәли башлау** Тетәләргә керешү

**ТЕТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тетү**. *Итек басучылар аңа тетелгән йонга заказ бирә дә, ул, хуҗалыклардан йон җыеп, шуны тетеп сата.* Шәһри Казан

2) Кием-салым, тукыма һ.б.ш. искереп, сизрәп, тузып бетү. *Курсантларның өс-баш, аяк киеме таушалган, тетелгән.* З.Мәхмүди

3) Бик нык ваткаланып, таралу хәленә килү. *Өйнең итәкләре тетелгән, теләсә ничек ямап, тарттырып куелган.* Н.Фәттах

4) *күч.* Сирәгәю, сыекланы, куелыгы киму (томан, төтен һ.б.ш. тур.). *Төтен тетелеп чыга тәрәзәдән.* М.Җәлил

5) *күч.* Бик нык ваклану, уалып таралу. *Басуның өсте тоташ казылган, туфраклары тетелеп ватылган иде.* Дәрдемәнд

6) *күч.* Бик фәкыйрь хәлгә төшү

7) *күч.* Тазалыгын, сәламәтлеген югалту, таушалу. *Бер гомердә мең кат алданылган, Өмет сүнгән, йөрәк тетелгән.* К.Булатова

8) *күч.* Бөтенләй бушану, онытылу. *Үлемне дә тоймас дәрәҗәдә тетелеп йоклады ул.* Н.Гыйматдинова

**Тетелә бару** Торган саен ныграк тетелү. *Мәйданнан читкә таба ераклаша барган саен, карасу төсләге киезләре искерә, тетелә барган тирмәләр күренә.* Г.Мөхәммәдова

**Тетелә башлау** Тетелергә тотыну; тетелүгә табан бару. *Инде тетелә башлаган кат-кат киемнәре, җәелеп киткән чабаталары аларның качаклар икәнлеген кычкырып тора иде.* Ф.Бәйрәмова

**Тетелеп бетү** Бик нык тетелү. *Кайбер ачык калдырылган шкафларның шүрлекләрендә читләре тетелеп беткән папкалар, кәгазь төргәкләре күренә ---.* М.Галәү. *Аяк киемнәре тетелеп бетте.* М.Мәһдиев

**Тетелеп тору** Тетелгән хәлдә булу; кагылуга ук тетелү. *Ералмасы [бәрәнге] әмән ком кебек, тетелеп тора. Көлдә пешкәнмени.* Г.Әпсәләмов

**Тетелеп чыгу** Тәмам эшкә яраксыз хәлгә килеп тетелү. *Айга бер тапкыр бирелә торган чабаталар инде өзелеп, тетелеп чыкты, кешеләр аларны эшкә күтәрмә тагып кия башладылар.* Ф.Бәйрәмова. *Теге ямаулы бишмәтем, черек булгандыр инде, тәмам тетелеп чыкты.* Безнең гәҗит

**ТЕТМӘ** *и.* Тетелгән йон; тетү өчен билгеләнгән йон. *Тетмәм дә юк эрләр өчен тарап, тетеп.* З.Бәшири

◊ **Тетмәсен тетү** 1) Тар-мар итү, таркату. *Казаннан соң урысларның Әстерхан ханлыгына ябырылулары белән үк, --- Мәскәүгә каршы тагын ике фронт ачып, тетмәсен генә тетәсе калган да бит.* Ш.Алпар; 2) Әрләү, сүгү, хурлау; бик каты тәнкыйть итү. *Бөкре карчыкның теле телгә йокмый, күршесенең тетмәсен тетә.* Д.Йосыпова. *Әткәйләрнең дә тетмәсен тетем.* Г.Галиева

**ТЕТРАЛО́ГИЯ** *и. гр.* Бер темага яки идеягә багышланган дүрт аерым әдәби яки музыкаль әсәрне берләштергән цикл. *Соңгы елларда ул дүрт романнан торган һәм «Кайту» дип исемләнгән тетралогия төгәлләгән иде.* Т.Нәҗмиев

**ТЕТРА́ЭДР** *и. гр. геом.* Һәр кыры өчпочмак формасында булган дөрес дүрткабыргалык; өчпочмаклы пирамида. *Тетраэдр – барлык кабыргалары тигез булган (яки барлык кырлары дүрт тигезьяклы өчпочмактан торган) кабарынкы төзек күпкырлык.* Геометрия. *Өчпочмаклы сөт пакетларын хәтерләгән кеше тетраэдрның ни икәнен белә булыр.* Сөембикә

**ТЕТРӘК** *с.* Тетрәүле, калтыраулы; тетрәп, калтырап торган. *Корбангали карт куркынган тетрәк тавыш белән: – Ул инде шулай. Бер килеш ята инде ул, – диде.* Ш.Камал. --- *ике матур кара күз, көләргә дә, еларга да әзер тетрәк иреннәр, гайрәтлелекне, тырышлыкны, хәтта бераз да гыйнадчылыкны күрсәтә торган мөнтазам таррак маңлай.* Й.Акчура

**ТЕТРӘНДЕРГЕЧ** *с. к.* **тетрәткеч**. *Бер вакыт радиодан Мостай Кәрим сүзләренә язылган «Өченче көн тоташ кар ява» дигән тетрәндергеч җыр тапшырдылар.* Б.Урманче. *Үзем өчен тетрәндергеч хакыйкатьне ачтым: ни хәл итмәк кирәк, әлеге алтылыктан бүген Илһаметдин белән тик икәү яшәп ятабыз икән бит.* Г.Гомәр

**ТЕТРӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн.* 1) *к.* **тетрәтү**

2) *күч.* Бик нык тәэсир итү; артык көчле хисләндерү. *Сәгъдәтне иң нык тетрәндергәне шул булды.* А.Хәлим

**Тетрәндерә башлау** Тетрәндерергә тотыну. *Шөһрәте белән уң-сулны дер селкетеп торган олуг тәхет иясенең кабергә керүенә үк мирасын бүлешү башланып, көннәр хәвеф эчендә туа вә бәндәләрне тетрәндерә башлады.* Ф.Яхин

**Тетрәндереп җибәрү** Кинәт тетрәндерү. *Бу көтелмәгән үлем Казан яшьләрен тетрәндереп җибәрә.* М.Мәһдиев

**Тетрәндереп кую** *к.* **тетрәндереп җибәрү**. *Үткәндәге гомеренең һәр шаһиты белән очрашу күңелен тетрәндереп куя, җан-бәгыренә көтелмәгән җәрәхәтләр сала иде.* Г.Гыйльманов

**Тетрәндереп тору** Даими, гел тетрәндерү; әледән-әле тетрәндерү. *Гарәп илләрен теракт арты теракт тетрәндереп тора.* Шәһри Казан

**ТЕТРӘНҮ** *ф.* 1) Үзеннән-үзе тетрәп, селкенеп тору. *Бөтен тирә-як кара янган. Бөтен нәрсә чайкала һәм тетрәнә.* Г.Бәширов

2) Калтырап тору, калтырану. *Әминәнең битенә кинәт кызыллык бәреп чык-*

*ты, иреннәре тетрәнеп куйды, йөзе әкренләп караңгыланды, иреннәре дә катып, агарып калдылар.* Р.Вәлиева

3) *күч.* Кинәт кенә көчле һәм авыр хис кичерү. *Тетрәнеп тәрәзәгә карыйм. Тышта йомшак кына ак кар төшкән, ак күбәләкләр сыман куыша-куыша...* Р.Ишморат. *Отелло бу илаһи тавышка чыдый алмый, тулып-ташып Дездемонага ташлана һәм үзенең саф, изге мәхәббәтенә кул суза... Зал сулыш алудан туктап тетрәнә.* И.Салахов

**Тетрәнә башлау** Тетрәнергә тотыну. *Кызның тавышы тулган ай нурына күмелгән иркен болын буйлап еракка таралды, сагыш-моң күкләргә ашып, сары ай тетрәнә башлады кебек.* М.Маликова

**Тетрәнеп алу** Бераз, берара тетрәнү. *Әле генә кара реакция ээзәрлекләүләре, тикшерүләр, төрмәләр, судлар белән тетрәнеп алган татар яшьләре каршына чыгып, Тукай тарихи оптимизм тулы сүзләрен әйтә.* М.Мәһдиев

**Тетрәнеп калу** Ниндидер вакыйгадан, тәэсирдән соң тетрәнгән хәлдә булу. *Авыр югалтудан тетрәнеп калган Әхмәровлар Салих белән Валентинаның кавышуына киртә куймыйлар.* Р.Зәйдулла

**Тетрәнеп китү** Кинәт тетрәнү. *Мостафинның бөтен тамырлары буйлап әйтерсең ток йөгерә: ихтыярсыз тетрәнеп китә ул...* А.Гыйләҗев

**Тетрәнеп кую** Кинәт тетрәнү; азга гына тетрәнү. *Йокыдагы Айсылу тетрәнеп куйды, борылып ятты.* Ф.Яхин. *Сиңа рәхәт, әмма утрау тетрәнеп куя.* М.Кәбиров

**Тетрәнеп тору** Даими тетрәнү; әле, хәзер тетрәнү. *Әнә бит, алсуланган нәфис борын яфраклары ничек тетрәнеп тора.* М.Маликова

**ТЕТРӘНҮЛЕ** *с.* Тетрәндерә торган. *Яшьлектә кичергән тетрәнүле тәэсир онытылмый икән.* Р.Фәйзуллин. *Бу минем өчен ачыш, тетрәнүле ачыш иде.* Ф.Яруллин

**ТЕТРӘТКЕЧ** *с.* 1) Селкетә, калтырата, тетрәтә торган

2) *күч.* Күңелгә бик көчле тәэсир итә торган. *Прокурор гаепләнүчеләргә үлем җәзасы таләп итте, ә мин үзенең ялкынлы, тетрәткеч чыгышым белән аларның гомерләрен саклап калдым.* М.Галәү. *Синең өчен бу җырның «баласын җуйган болан эзеннән» дигән сүзләре тетрәткеч булса, бәлки, кемгәдер аның «башканы сөям» дигән сүзе барып ишетелер, дип куркам...* А.Гыйләҗев

**ТЕТРӘТҮ** *ф. йөкл. юн.* 1) Дер селкетү, калтырату. *Җир тетрәтеп, күпер ишелде.* М.Җәлил. *Таң беленә башлаганда, кыяны нигезенә кадәр тетрәтеп, ике җирдә бик каты шартлау ишетелде.* Г.Әпсәләмов

2) Күңелдә көчле хис кузгату. *Иптәш, синең музыкаң таш йөрәкләрне дә тетрәтә.* Г.Ибраһимов. *Җан тетрәтеп килде көз башы.* И.Сабиров

3) Куркыту, шом салу. *Казанлылар Сөен-бикә телләгәнчә эш итсәләр, атасы Йосыф мирза, шулай ук нугай мирзалары Казан ханлыгына ярдәмдә булсалар, Казанның беренче ханлык булып калачагы вә шуның нәтиҗәсендә урысларны тетрәтеп торачагы билгеле иде.* Һ.Атласи

**Тетрәтә башлау** Тетрәтергә тотыну. *Яңа кәнәфигә менеп утыргач та, Борчак Сәлименең ярсулы сүзләре һаваны тетрәтә башлый.* Р.Низамиев. *Менә бүген дә, яр астыннан дөнья җимерелгән тавышлар авылны тетрәтә башлагач, Текә Яр халкы, иртә таңнан ук бердәм кубып, ташу карарга йөгерде.* Ф.Баттал

**Тетрәтеп кую** Кинәт тетерәтү. *Кәшәкәчеләр төртешкәләп тә алдылар, һәм, «Ак барс» капкасы янында мәхшәр булып, буталыш җанны тетрәтеп куйды.* Ф.Яхин

**Тетрәтеп тору** Даими тетрәтү; әле, хәзер тетрәтү. – *Сезнең бабаларыгыз тикмәгә генә ике йөз ел урысларны тетрәтеп тормаган икән шул!* – *ди.* Р.Батулла

**ТЕТРӘ́Ү** I *ф.* 1) Калтырап селкенеп тору (гадәттә зур, массив нәрсәләр тур.). *Бераздан җир тетри башлый, һәм ул тетрәү көчәйгәннән-көчәя бара.* М.Яһудин

2) Калтырану, калтырап кую. *[Нәфисәнең] җирәнү һәм хурланудан бөтен тәне тетрәде.* Г.Бәширов

3) Өзек-өзек булып чыгу (тавыш тур.). *Аңа кирәкле зур «ТУ» соры бетон тасманың иң аргы башында, очарга хәзерләнеп, инде борылып ята, аэродром өстендә, таш-тау җимерелгән сыман, каты гөрелте тавышы тетрәп тора иде.* М.Зарипов

4) Кискен һәм авыр хисләр кичерү (*җан, күңел* кебек сүзләр белән). *Язмышыңнан тетри җан, Рухлар елый, җир селкенә.* Һ.Такташ. *Әмма кыз туктамады, күзләреннән яшь акты, җаны тетрәп үкседе, кемнәндер куркып качкан төсле чапты да чапты.* Ф.Яхин

5) *күч.* Курку, куркыну. *[Исмәгыйль:] Минем исемем ишетелгәндә, бөтен тирә халкы тетрәп торалар.* М.Фәйзи

**Тетри башлау** Тетрәргә тотыну. *Тукай бәйрәмен үткәрәсе көнне таң алдыннан, ягъни 26 апрельдә, Ташкентта җир тетри башлый.* Р.Батулла

**Тетрәп калу** Кинәт, көтмәгәндә тетрәү. *Олуг Мөхәммәд хан, шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, үзенең 3000 кешелек гаскәр башында торып, князь Василий II гаскәренә һөҗүмгә ташлана. Мондый кыюлыкны көтмәгән рус гаскәре тетрәп кала ---.* М.Әхмәтҗанов

**Тетрәп китү** Кинәт тетрәү. *Тетрәп китәм – сезгә әйтелмәгән Рәхмәтләрем җанда тулгак тота.* Р.Хисмәтуллин. *Әлфия апа сөйләгән соңгы тарихтан мин тагын бер тетрәп киттем.* Г.Җәлилова

**Тетрәп кую** Кыска гына ара эчендә тетрәү. *Тетрәп куйды йөрәк – Нәкъ шул мәлдә сине яраттым.* Зөлфәт

**Тетрәп тору** Өзлексез тетрәү; әле, хәзер тетрәү. *Галәм иңләр акыл тетрәп тора селкенмичә яткан тәндә дә.* З.Мансуров. *Күпмедер вакыт җир тетрәп торды.* Ялкын

**ТЕТРӘ́Ү** II *и.* 1) Калтырану, дерелдәү, селкенү күренеше. *Этләр җир тетрәвен алдан сизәләр, дип әйтәләр.* Г.Әпсәләмов. *--- бу һичкем теләмәгән сугышның башлануы аның өчен җир түгел, кояш тетрәвеннән яманрак булган иде.* Ә.Еники

2) *күч.* Тетрәнү, көчле, авыр кичереш. *Ачуы, ярсуы чамадан тыш көчле эчке тетрәүгә әйләнеп, мәтнең чыраен*

*бугандагы кебек зәңгәрләтте, баклажан төсенә кертте.* Ә.Гаффар

**ТЕТРӘҮЛЕ** *с.* 1) Тетри торган; аз гына калтырап, дерелдәп тора торган. *Аның [Мәрьямнең] тетрәүле матур тавышы әле дә булса Мохтарның исеннән чыкмый иде.* Ш.Камал

2) Тетрәүләр (II) белән барган. *Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев --- тетрәүле, каршылыклы үзгәртеп корулар чорында да Республикабызны җитәкләп, хәвеф-хәтәрсез, газиз Тукаебыз әйтмешли, «җиктереп пар ат, туры юлына карап», чаптырып алып керде безне Яңа гасырга да!* Безнең гәҗит

**ТЕТРИЛ** *и. лат.* Кристаллик төзелешле бик көчле шартлагыч матдә, капсюль дарысы. *Һәр мина ярылган саен, актарылып ялкын күтәрелде. Тетрил исе аңкытып, җир өстенә куе төтен җәелде.* Ф.Кәрим

**ТЕТТЕРЕП** *рәв.* 1) Каты итеп, мул итеп. *Менә яңгыр теттереп ява башлады.* Г.Газиз

2) Бик тиз итеп, бер дә тоткарланмыйча, иркен, рәхәтләнеп (сөйләү, сөйләшү һ.б.ш. тур.). *Өлкән брат белән уртанчы брат үзара теттереп русча сөйләшәләр, ди.* М.Әмир. *Кешенең әле генә итәгеннән төшеп җиткән баласы да теттереп урысча сукалый, диген...* Р.Гаязетдин

**ТЕТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тетү**. *Районнан йон теттереп кайтып килә икән.* М.Әмирханов

2) *күч.* Нинди дә булса эшне бик шәп, әйбәт, күңелле итеп башкару. *Мактый инде Тинчуринны, теттереп мактый.* Р.Батулла. *Журналист халкы үткер шул, чит илнекеләрне теттереп тәнкыйтьлиләр, үзебезнекеләр турында гына ләм-мим.* Ф.Дәүләтбаев

**Теттерә башлау** Теттерергә тотыну

**Теттереп алу** Берара теттерү; бераз теттерү

**Теттереп кую** Тиз арада теттерелгән итү

**ТЕТҮ** *ф.* 1) Аерым сүсләрдән, җепселләрдән торган һәм укмашкан нәрсәне яңадан сүсәртү, тарткалап йомшарту; язу. *Әнкәй теткән йондай Карлар коела күктән.* М.Җәлил. *Шул ук чыгыр һәм кәҗә мамыгын тетә торган ая да бар.* Х.Исмәгыйлев

2) *күч.* Җимерү; бөтенлеген бозу, тузгыту. *Чит кешеләр бакчасын таптыйм, тетәм.* Г.Тукай. *Кара җанын тетеп фашизмның, Үләксәсен ташлыйк этләргә.* М.Җәлил

3) *күч.* Кемнедер бик нык тиргәү, хурлау, яманлау. *Кайсы колхоз персидәтеле мәктәп директорын булышмый дип эләкләгән дә, аны шул трибунадан ничек тетәләр?!* Р.Газиз. *Әбиләр тетә генә безне.* Безнең гәҗит

**Тетә башлау** Тетәргә керешү. *Ул шулай дип әйтүгә, сәхнәгә түше белән үк диярлек яткан Гыйльми Салихы чәчрәп чыкты да председательне тетә башлады.* А.Гыйләҗев

**Тетеп бетерү** Бик нык тетү; тетүне тәмамлау. *Көчле җил һәм боз бакчадагы барлык яшелчәләрне: бәрәңге, помидор, кыяр, суган һәм кәбестәне йолкып, тетеп бетерде.* Дуслык

**Тетеп кую** Алдан яки тиз арада тетү; гомумән тетелгән хәлгә китерү. *Җырның сүзләрен ул үзенчә тетеп-тетеп куя, ул кисәкләрне тоташ моң белән, көй белән төрә дә аннары гына безнең арага тарата иде бугай.* М.Мәһдиев

**ТЕФТӘ** *и. фар. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан үлән арасында үсә торган вак кына үсемлекнең бер төре; *русчасы*: **донник**

2) Кандала үләне

3) Шул үләннән ясалган пластырь. *Ярага тефтә капладылар*

**ТЕХ-** *рус* Кушма сүзләр составында «техник, техникага бәйләнешле» дигән мәгънәне белдерә торган беренче компонент (мәс., *техперсонал, техпропаганда, техредактор*)

**ТЕХМИ́НИМУМ** *и. рус* Нинди дә булса бер һөнәрнең техник белемнәр минимумы. *Техминимумымны да сездән алган белем белән отличнога бирдем.* Г.Кутуй. *Бүген үк техминимум брошюраларын карап чык, хәбәрдар булырга ярдәм итәр.* С.Сабиров

**ТЕ́ХНИК** I *с.* 1) Техника (*1 мәгъ.*) белән бәйле; шул өлкәгә караган. *Ә бер ярты сәгатьтән бригадага техник ярдәм машинасы килеп җитте.* Н.Фәттах

2) Техниканы өйрәнүгә, куллануга яки үстерүгә бәйләнешле. *Лицейның матди һәм техник базасын ныгыту, укыту-тәрбия эшләрен нәтиҗәле, максатчан алып бару өчен шартлар тудыру юнәлешендә зур тырышлык куйды.* Г.Мөхәммәтшин. *Техник прогрессның космик адымнар белән алга китүе --- матбугат, радио, телевидение информациясе – боларның һәммәсе дә бер телдән икенче телгә яңа сүз керүне туктаусыз ихтыяҗ итә.* Х.Сарьян

3) Механизмнарны һәм машиналарны эшләтү процессына караган. *Әгәр дә оештыра алмасак, әгәр дә колхозга керүчеләргә техник киррәкләрен җиткезә алмасак, шул чагында ни дип җавап бирербез?* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Бобровкага тиздән техник үзенчәлекләре белән бөтенләй башка югарылыктагы яңа самолётлар – МИГ-19ның беренче үрнәкләре кайтырга тиеш, диган хәбәр таралды шул көннәрдә.* Р.Мөхәммәдиев

4) Төрле техниканы (машиналарны һ.б.ш.) куллану, файдалану белән бәйле булган. *Техник бүлек*

5) Техника өчен кирәк булган яки эшкәртелергә тиешле. *Цех, әлеге дә баягы, техник кислотадан тыш, берникадәр күләмдә реактив сыйфаттагысын да эшләп чыгара иде.* Э.Касыймов

6) Берәр нәрсәне эшләү, ясау, иҗат итүдә махсус күнекмәләргә бәйле булган. *Спортчылар югары әзерлек һәм техник осталык күрсәтте.* Кызыл таң

7) Җитәкче яки белгечләрнең кушканын үтәп йөри торган (хезмәткәрләр тур.). *Техник секретарь*

**ТЕ́ХНИК** II *и. рус* 1) Урта техник (I) белеме булган хезмәткәр. *Аларның өлкән улы Искәндәр, техникум тәмамлап, кайбер алман егетләре дә башкара алмаган эшкә – тимер юл хезмәтенә техник булып урнашты.* Т.Әйди

2) Техника өлкәсендә эшләүче кеше. *Шул ук көнне кич белән, мин күрше авылларның берсенә киткән арада, Корбанов, Галиуллин һәм техник – өчәү – амбулаторияне килеп караганнар.* Г.Кутуй

**ТЕ́ХНИКА** *и. рус тех.* 1) Житештерү өлкәсендә кулланыла торган хезмәт кораллары, чаралары һәм акыл

эшчәнлегенең шуларны өйрәнүгә, куллануга, камилләштерүгә бәйле өлкәсе. *Хәзерге заман компьютер техникасы һәм башка төр прибор, машиналар теле инглиз, латин графикасына корылган бит.* Ә.Кәримуллин. *Ә беләсезме ни өчен японнарның техникасы алда, тормышы бай, матур?* Р.Батулла

2) Хезмәт чараларын куллануның билгеле бер тармагы, шул тармакка караган фәнни-гамәли нигезләр

3) Машиналар, җайланмалар, җиһазлар. *Эшче көчләр җитешми, техника бик шәптән түгел.* Ф.Хөсни. *Ниһаять, миңа да бәхет елмайды: хәрби техника төягән транспортка эләгеп, Утраулардан качтым һәм, ничек итсәм итеп, Манилага килеп җиттем.* И.Хуҗин

4) Билгеле бер эштәге алымнар һәм ысуллар җыелмасы. *Болар миңа сулыш алу техникасын, тавышның тергә кайда икәнен күрсәттеләр...* Р.Батулла. *Бары тик ул гына сөйләм аппаратын хәрәкәткә китерә һәм әйтү техникасын сөйләүченең иҗади ихтыярына буйсындыра.* Ш.Асылгәрәев

5) Сәнгатьтә тышкы осталык һәм һәрбер сәнгать вәкиле үз өлкәсендә яхшы белергә тиеш булган алымнар системасы. *Аның язучылык техникасына ия булу, әдәби алмаш тәрбияләү турында әйткәннәре истә калган.* С.Хәким. *Димәк, шигырь техникасы, поэзия дөньясы аңа практик рәвештә таныш.* А.Гариф

**ТЕ́ХНИКУМ** *и. рус* Урта техник яки гомумән махсус урта белем бирә торган уку йорты. *Тәнзилә – авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган кыз – хезмәт практикасыннан соң, Мәскәүдә Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясенә имтихан бирүен хәбәр итте.* А.Хәлим. *Техникумның китапханәсе искиткеч бит.* А.Хәсәнов

**ТЕ́ХНИКУМЧЫ** *и. сөйл.* Техникумда укучы. *Без, елгачылар больницасының яшелчә бакчасына кәбестә алышырга баручы бер төркем шәфкать туташлары һәм техникумчылар, кичтән сөйләшенгәнчә, иртән порт идарәсе ишегалдына җыелган идек.* С.Сабиров

**ТЕХНИЦИЗМ** *и. рус* 1) Билгеле бер эшнең техник ягы белән аның эчтәлегенә, асылына зыян китерерлек дәрәҗәдә мавыгу күренеше. *Шпенглер әйтүенчә, иртәме яки соңмы Көнбатышта, андагы гавам исән калган хәлдә, бүгенге шәрә, җимергеч техницизмга алмашка иҗади һәм рух үсешен алга сөргән яңа культура туачак.* Н.Шәрифуллин

2) *әд.* Матур әдәбиятта техниканы тасвирлау белән мавыгу юнәлеше. *Башкорт әдәбияты галиме К.Әхмәтйәновның раславына караганда, Һ.Такташ һәм Х.Туфан иҗатлары тәэсирендә башкорт шигърияте техницизмнан, машинизмнан тизрәк арына.* Ф.Галимуллин

**ТЕХНИ́ЧКА** *и. рус сөйл.* 1) Җыештыручы хатын-кыз, хезмәт күрсәтүче персонал. *Техничкалар, кайсы чиләк, кайсы щётка тоткан булып, классларга таба сибелделәр.* М.Мәһдиев. *Техничка Миңлебикә кыңгырау шалтыратырга мәҗбүр булды...* К.Кәримов

2) Юлдагы автомобильләр, тимер юл һ.б.ш.ны төзәтү өчен җибәрелә торган махсус автомобиль, техник ярдәм машинасы

**ТЕХНО́ЛОГ** *и. гр.* Җитештерүнең кайсы да булса тармагында технология белгече. *Бер технолог сызым сыза, башын кашый.* Г.Афзал. *Барысы да тәртиптә икән, тик бер технолог Мөсәлләм генә зарланып алды.* Г.Шәйхи

**ТЕХНОЛО́ГИК** *с.* Технологиягә бәйләнешле, шуңа хас. *Без Европаның гуманистик һәм технологик казанышлары белән горурланабыз.* А.Тимергалин

**ТЕХНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Җитештерүнең билгеле бер тармагында эшкәртү алымнары, ысуллары җыелмасы. *Нәшрият «казанын»: китапны басарга әзерләү, текстны төзәтү, аны төрле экстралингвистика, полиграфия чаралары белән тулыландыру, бизәү, авторлар белән эш итү технологиясенең чын белгече --- энциклопедик белемле, эрудицияле галим-мөгаллим иде ул.* И.Низамов. *Укытучыларыбыз мондый әңгәмәләрдә балаларга әзер әхлакый нормалар биреп кенә калмыйлар, иҗади үсеш технологиясенә нигезләнеп, --- анализ ясарга өйрәтәләр.* З.Исламов

2) Шул алымнар, ысуллар җыелмасының фәнни тасвирламасы. *Аннары көнгә чигү тарихы һәм технологиясе белән танышабыз.* Р.Бәшәр

**ТЕХНОРУК** *и. рус* Техник җитәкче. *Зур папка тотып, Һарун, технорук, партия вәкилләре, цех начальниклары, инженерлар керә.* Т.Гыйззәт. *Технорук өйдә юк.* Г.Кутуй

**ТЕХСНАБ** *и. рус* Техник яктан тәэмин итү белән шөгыльләнә торган оешма. *Рус Акташында ике фатир урнашкан бер йортның түбәсе, Техснаб районындагы мунча, Нефтьчеләр урамында Ниссан-Тиана автомобиле электр үткәргечендәге кыска ялганыш аркасында янгыннан зыян күрә.* Әлмәт таңнары

**ТЕШ** *и.* 1) Авыз куышлыгында ашамлыкны тешләп алу, чәйнәү яисә вату өчен хезмәт итә торган, аскы һәм өске казналыклар буйлап ике параллель рәт ясап тезелгән сөяк үсентеләрнең һәрберсе. *Аның да вакыт-вакыт тешләре сызлап куя.* А.Хәсәнов. *--- бозау чаклы эт тешләрен ыржайтып аңа карап тора.* З.Хөснияр

2) Кайбер махсус җайланмаларда, коралларда тигез ара калдырып урнашкан чыгынтыларның берсе. *[Шәмсия кылычны күтәреп карап:] Моның алты-җиде тешен сындырганнар.* М.Гафури. *Мин шестерняларның тешләрен, хедерның бармакларын санап карыйм.* Г.Галиев

3) Нинди дә булса эш кораллары, механизм һ.б.ш.ларда нәрсәне дә булса эләктерү, эләктереп тарту, эләктереп өзү өчен ясалган очлы чыгынты. *Җиргә ипсез сугылып, тырма теше дә сынып чыкты.* З.Мурсиев. *Уракның тешләре коелган, буш нигезләр күп.* Р.Батулла

◊ **Теш агарту** 1) Авыз ачып кирәксез, урынсыз сүз әйтү; тын чыгару; сөйләп ташлау, кирәкмәгәнне ычкындыру. *Ишетсен колагың: әти алдында тешеңне агартасы булсаң, бел аны!* Г.Бәширов. *Ул хакта теш агартып сүз әйтәсе булма миңа!* В.Нуруллин; 2) Елмаю, авыз еру. *Һәрнәрсәдән кызык табып, теш агартырга сәбәп эзләп утыручыларга бу җитә калды.* М.Хәсәнов. **Теш азаулану** Нинди дә булса эштә һәртөрле кыенлыкларга каршы көрәшеп тәҗрибә туплау; азау

яру. *Төзелешләрдә теше азауланып беткән, өченче көн генә акыллы киңәшләр, төпле фикерләре белән җанны эреткән, юаткан Туркин бүген берни дәшми.* А.Гыйләҗев. **Теш арасына кыстыру** Нәрсәне дә булса азык урынына ашау турында. *Бондаренко! Теш арасына кыстырырдай ниең бар?* Х.Хәйруллин. *Син безгә теш арасына кыстырырлык берәр нәрсә бирә алмассыңмы, икебез дә ач.* Р.Батулла. **Теш арасыннан** Ачу, ризасызлык, мыскыллау һ.б.ш.ларны белдереп әйтү, сөйләшү турында. *– Мине эштән алсалар, карап карарбыз әле, – диде ул, сүзләрен тешләре арасыннан сөзеп, – яңа директор ни кыйратыр икән.* А.Вергазов. *Сүзен ул теш арасыннан сайлап кына чыгара, чамалап кылана.* Д.Зөбәерова. **Теш арасыннан (тартып, каерып) та алып булмый** Эчендәгесен һич белдерми торган, серле яки гомумән бик аз сүзле кеше турында. *Сарҗан агай иң кирәклесен дә теш арасыннан тартып алып булмый торган йомык бер адәм икән.* С.Рафиков. **Теш белән әргән уйнау** Туңудан теш тешкә тимәү, калтырау, дерелдәү. *– Күрәсең ич, теше белән ничек итеп әргән уйный, боз астын күрмәгәч, без беребез дә алай уйный белмибез, – дип тешләрен ыржайттылар икенчеләре.* Ф.Хөсни. **Тешен кою** *к.* **тешен чүпләү**. *Сиздек эшеңне, коярбыз тешеңне.* Әйтем. **Тешен санау** *к.* **тешен чүпләү**. **Тешен чүпләү** Авызга сугып тешләрне төшерү. *Мин, үз тешемне калдыруга караганда, кеше тешен чүпләүне артыграк күрәм.* Ф.Хөсни. **Теше сирәк** Сер тотмас. *Имеш, минем тешем сирәк, авызымда сүз тормый.* Т.Гарипова. **Теше тешкә тимәү** Артык туңудан яки куркудан авыз тирәсе калтырау, дерелдәү турында. *Коя гына яңгыр, кая барсыннар инде бу бичаралар, күшегеп беткәннәр, тешләре тешкә дә тими...* Р.Батулла. *Туңудан калтырап, тешләре тешкә тия башлагач, яңгыр суын чапылдата-чапылдата бер урында сикергәләргә тотынды.* Р.Вәлиев. **Теше чыгу** Нинди дә булса эштә озак эшләп, тәҗрибә туплау, остару. *[Сафиның] Тире сатып, йон алып чыккан теше.* Г.Тукай. *[Һидият белән Җаббар] балык тотып тешләре чыккан халык.* Ш.Камал. **Теш кайрау** 1) Ашарга җыену; ашыйсы килү. *Көтә бу кыздырган балык, тешен кайрый. Хатыны моның алдына бер табак салма китереп куя.* Әкият; 2) Үч алырга җыену, үч тоту, үч саклау. *Ачуы хәттин ашкан иде: теш сызлавын да онытып, сакчыга теш кайрады.* Д.Булатова. *Теш кайрап йөрүеңне мин бик яхшы сизәм.* Г.Кутуй; 3) Нинди дә булса эш башкарып ташларга җай, сылтау яки вакыт чамалау. *Пристав күптән теш кайрап йөргән мәдрәсәне бикләп куярга бик уңайлы сылтау тапкан икән.* С.Кудаш. *Беләм, анда бар да миңа теш кайрыйлар...* А.Гыйләҗев. **Тешкә тию** Эчне пошыру, нервыга тию, борчу. *Төерле тел тешкә тия.* Мәкаль. *Шаушу тешкә тиярлек дәрәҗәгә җитә башлагач, Солтан, уң кулын күтәреп, тынычлык сакларга чакырды.* А.Расих. *Тешкә тия торган «инородец» атамасы сүзлектә «әҗнәби» дип бирелә.* А.Тимергалин. **Теш корты** 1) Сызлый торган, авыру тешнең нерв очлары ялкынсынуы. *Теш кортын дошманыңа күрсәтмәсен!* Д.Булатова; 2) Җанга төшеп, бик ялыктыра торган нәрсә. *Карлыгач атын ашыктырырга тотынды. Күк байтал: «Әй, теш корты булдың ич, таманысы!» – дигәндәй, дилбегә тартканга койрыгын гына селкеп куя иде.* Г.Бәширов. **Теш күрсәтү** Ныклы чаралар кулланып көрәшергә, сугышырга әзер икәнлекне белдерү. *Борһан бер дә юкка кайнап, ачуыннан ярсып утыра бирде: «Мин – карт бүре, минем әле сезгә генә тешемне күрсәтерлегем бар».* М.Хәсәнов. *– Озатып карагыз... – дип, тешен күрсәтеп маташты.* А.Тимергалин. **Теш кыҗрау** *к.* **теш кайрау**. *Чын батыр яу кыйраганда кул башлар, чын чәчән теш кыҗраганда сүз башлар.* Мәкаль. **Теш кысу** 1) Нинди дә булса халәткә: рухи көчәнеш, ачу, ярсу, авырту һ.б.ш.га түзү; 2) Барлык көчеңне, ихтыярыңны туплау, түзү, чыдау. *Авыр вакыты була – теш кысып яшисең.* М.Мәһдиев. *Авыр чакларда күңелеңне көлке-мәзәк белән юата идеңме, әллә теш кысып түзәргә туры килдеме?* Р.Вәлиев; 3) Бик нык ачуланып ярсу, рәхимсезләнү. *Теш кысып ата.* Ф.Кәрим. *Нигә Василий җиңел генә гаризасын тартып алды? Тешләрен кысып, усалланып язган иде бит ул аны.* А.Гыйләҗев. **Теш сугу** Үз мәнфәгатең өчен бәхәсләшү, сатулашу, телләшү. *Хәйрулла белән Андрей, бик зур эш күндереп кайткан шикелле, үзләренең «сәфәр мәшәкатьләре», анда баргач, буфетчыны таба алмыйча аптырауларын, аның белән ничек сатулашу, теш сугулары турында үзләренчә бик кызык иттереп сөйләргә азаплана иделәр.* Ш.Камал. **Теш суыру** 1) Теш арасыннан сызгыртып эчкә һава алу. *– Да, ни мишалы бы берәр кырыкмышны суйганда, – дип куйды Баһави, тешен суырып.* А.Расих; 2) Ашарга булмау, ач утыру. **Теш төбенә төшү** Үзәккә үтү, бик нык йөдәтү. *Аның [Гәрәйшаның] теленә эләксәң, теш төбеңә төшә инде ул.* Ш.Маннур. **Теш төшү** Нәрсәне дә булса озак көтеп, картаю. *[Гыйният – Исхакка:] Син булмыйча? Син дип теше төшә ич инде ул Сафиянең.* Н.Исәнбәт. **Теш уңае** Сылтауга уңай килеп тору турында. *Бу тамаша шәкертләргә теш уңае булды. Алар сугышка китүче солдатларны тамаша кылуны үзләренә гадәт иттеләр.* К.Тинчурин. **Теш үтү** 1) Тешләр белән чәйнәп ашый алу. *Кара икмәкне кимердек, Теш үтмәс каты көйгә.* Г.Камал. *Чикләвекләрең булса ни, Гатауның тешләре синең чикләвекләреңә генә үтәрлек.* М.Фәйзи; 2) Кемне, нәрсәне дә булса усаллашып җиңү, каты көрәшеп яки көчле тәэсир итеп үзеңнекен булдыру. *Чыннан да, Тукай могҗизасы күпләр өчен теш үтмәс каты төен булды.* Р.Батулла; 3) Китап, гыйлем, фән кебек катлаулы нәрсәләрне аңлый алырлык булу. *Иркенләп китап укыйм дисәм, китаплары бөтенләй кызыксыз булып чыкты. Теш үтмәслек химик формулалар белән тулганнар.* А.Расих. *Әле хәзергә гарәп белән фарсыга минем тешем үтми иде.* Г.Бәширов. **Теш шакылдату** 1) Ашарга таба алмыйча, ач тору турында; 2) Суыктан калтырау. *Бу комсыз нәрсә [тимер мич] бер атна эчендә бөтен утыныңны ашап*

*бетерер. Утыр аннары тешләреңне шакылдатып.* А.Шамов. **Теш шыгырдату** 1) Ризасызлык күрсәтү, ачулану, ярсу. *Ә Шәукинең күршесенә ачуыннан тешләре шыгырдады, рәнҗүдән күз яшьләре бәреп чыкты, үзе ыңгырашты, «су, су» дип саташты.* Р.Гаффар; 2) Һөҗүмгә атлыгып, ярсып тору. *Исерек атаның тавыш чыккан саен әнисен яклаган малаена булган нәфрәттән каны кайнады, күзләре кыргый этнеке шикелле ялтырады, ач бүренекедәй тешләре шыгырдады.* Г.Гыйльметдинова. **Теш шытырдату** *к.* **теш шыгырдату**. **Теш ыржайту** 1) Мәгънәсез, кирәкмәгәнгә көлү, теш агарту, авыз еру. *Елмая дисәң дә ярый, димәсәң дә: тешен ыржайткан.* А.Тимергалин; 2) Ачуын күрсәтү, янау, куркыту. *Шигырьләренә һәм фельетоннарына кертелгән байгуралар һәм кадими затлар шулай ук таралышкандыр, димәк, оясына поскан эттәй теш ыржайтып калучылар булмас.* М.Хуҗин. *Ни миче, ни савыт-сабасы булмаган, һәр почмагыннан фәкыйрьлек, ачлык, үлем теш ыржайтып торган бу йортта күчеп килүчеләргә үрнәк булырдай бернәрсә дә күренми иде ---.* М.Галәү. **Теш ялтырату** Күп сөйләшү, сер тотмау. *Малайлар әле серне белмиләр, әпен-төпен килеп теш ялтыратучы, серне бик тиз чишүче без түгел.* К.Миңлебаев. **Теш ястыгы** Ризык, ашамлык. *Ашармын, тик теш ястыгыңны гына кызганма.* М.Әмир

**ТЕ́Ш АНАСЫ** *и.* Бәбинең беренче тешен башкалардан алда күргән хатынкыз

**ТЕШӘВЕЧ** *и.* Эш коралларын теши торган кискеч яки игәү. *Тешәвеч сабы*

**ТЕШӘК** *с.* Теш чыгара торган, тешәү яшендә булган. *Тешәк сарык*

**ТЕШӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тешәү** II. *[Уракны] тимерче Гаптеригә илтеп тешәтеп җибәрә идем, яңа урактай ялт итә иде.* Г.Мөхәммәтшин

**ТЕШӘ́Ү** I *ф.* Билгеле бер яшьтәге хайваннарның һәм кешенең кайбер тешләре алмашыну. *Туксанда теш төшәр, йөздә яңадан тешәр.* Мәкаль

**Теши башлау** Тешәргә тотыну. *Мин алты яшьтән узгач теши башлаганмын...* Р.Батулла

**ТЕШӘ́Ү** II *ф.* 1) Тешле кисү, уру коралларының тешләрен үткенләү. *Аларның бабалары Ногман Шәрәфиев гап-гади тимерче булган. Бигрәк тә кул уракларын оста тешәгән.* Т.Нәҗмиев

2) Тешләр, чыгынтылы детальләр ясау. *Менә хәзер ул картайган, аның чаларган сакалы, үзе тешәгән соры кабага охшап, сирәкләнеп калган.* Г.Бәширов

**Тешәп алу** Тиз генә бераз тешәү

**Тешәп кую** Алдан ук тешәү

**Теши башлау** Тешәргә тотыну

**Теши төшү** Тагы да бераз тешәү

**ТЕШӘҮЛӘ́Ү** *ф. к.* **тешәү** II. *Башта вак-төяктән генә керешә бу: кемгәдер урак тешәүләде, чалгы тапады, кайрады...* М.Хәсәнов

**ТЕШӘҮЛЕ** *с.* Тешәлгән, сырлары, тешләре яхшылап ясалган. *Шулай да Гапсаттарның борыны ис сизүчән, корсак эчендәге тегермән ташлары тешәүле аның.* Ф.Яхин. *Ике көпчәкле арба тартып, үз кулы белән җеген җеккә берәмтекләп утаган, тешәүле урак белән урган, шәп итеп тапалган --- үләнне тартып кайткан юллар --- Хәйгә ел буена җитәрдәй әллә нинди бер ләззәт тойгысы бирә торган иде.* Ә.Гаффар

**ТЕ́Ш БАКАСЫ** *и.* Тештә яки казналыкта булган ялкынсыну нәтиҗәсендә барлыкка килгән үлекле шеш; флюс

**ТЕ́Ш ВРАЧЫ** *и.* Тешләрне дәвалаучы белгеч, стоматолог, дантист. *Теш врачына кагылган идем, чират.* А.Гыйләҗев. *Ярар, ярар, син психотерапевт түгел, син – теш врачы.* З.Хәким

**ТЕ́Ш ДОКТОРЫ** *и. к.* **теш врачы**. *Ярулла теш докторына барырга курка.* Г.Кутуй. *Бу ханым, соңыннан тагын укып, теш докторы була.* Т.Әйди

**ТЕШЕ** *с.* Инәк, ана (хайваннар тур.); *киресе*: **иркәк**. *Арысланның иркәге дә арыслан, тешесе дә арыслан.* Мәкаль. *Шәрифулла абзый бер бик матур теше бозау җитәкләп кайтты.* Х.Сарьян

**ТЕШКАРА** *и. иск.* Тешкә матурлык өчен ягыла торган махсус кара буяу. *Абау, җаным, тешең кара, Кайдан алдың тешкара?* Җыр. *Ак җария йөзе ап-ак булып, кап-кара итеп тешкара сөрткән.* Н.Исәнбәт. *Хәзерге яшь буын тешкараның нәрсә икәнлеген дә белми.* Ватаным Татарстан

**ТЕ́Ш КАРАСЫ** *и. иск. к.* **тешкара**. *Сара, тешләрен каралтыр өчен, теш карасы чәйни.* З.Бәшири. *Бабай язган васыять кәгазен дә Күралмадым, – күптән җуйганнар; Әллә шунда кыяр орлыклары, Теш карасы төреп куйганнар...* Ш.Галиев

**ТЕШЛӘК** *с.* 1) Тешли, тешләшә торган. *Нуриев аның кулын каты итеп тешләде, Арнольд кычкырып җибәрде: – А-а, бу урыс тешләк икән!* Р.Батулла. *Әйбәт журналист булу өчен, эт кебек тешләк, эт кебек уяу, эт кебек әрсез, эт кебек куркусыз һәм хуҗаңа эт кебек тугры булу кирәк.* Н.Фәттах

2) *куч.* Астан гына эш йөртә торган, усал. *Исхак кечкенәдән үк үзсүзле, тешләк булып үсте.* С.Рафиков. *Берсе тешләк, усал һәм үчле булса, икенчесе самими, ышанучан һәм күңелчән иде.* Г.Гыйльманов

3) *куч.* Үз эченә бикләнгән, йомыкый. *Поликлиника сакчысы бигрәк тешләк, каныгучан адәм булып чыкты.* Д.Булатова. *Тешләк иде бит Җамал, минем күзгә караган да каткан.* А.Әхмәтгалиева

**ТЕШЛӘКЛӘНҮ** *ф.* Тешләккә әйләнү, тешләк булып китү. *Улының тешләкләнеп берни әйтми ятуы аның җенен котыртты.* А.Гыйләҗев. *Сәясәт тирәсендә тешләкләнеп, карьера хакына теләсә кемне юкка чыгарырга әзер кешеләр дә була.* Р.Мөхәммәдиев

**Тешләкләнә башлау** Тешләкләнүгә табан үзгәреп кую

**Тешләкләнеп алу** Берара тешләкләнү

**Тешләкләнеп бетү** Нык тешләкләнү

**Тешләкләнеп тору** Күпмедер вакыт тешләкләнү

**ТЕШЛӘМ** *и.* 1) Түзелеше ягыннан караганда авыздагы ике рәт тешләр теземе. *Авыру биз тешләргә начар тәэсир итә, аларның үсешен тоткарлый, ачык тешләм (алгы тешләрнең кушылмавы) формалаша.* Кызыл таң. *Тешләмнең дөреслеге*

2) *диал.* Кабым

**ТЕШЛӘНҮ** *ф. төш. юн.* 1) *к.* **тешләү**. *Тешләнгән, яраланган бүреләр, авыртуга түзә алмыйча улый-улый, бер читкә китеп яраларын ялыйлар.*

Р.Батулла. *Мин хәзер – тешләнгән алма, мин хәзер – сагыш йорты.* Р.Харис

2) Тешләр, чыгынтылар барлыкка килү. *Тешләнгән урак*

**Тешләнә башларга** Тешләре беленергә. *Пычак йөзе тешләнә башлаган*

**Тешләнеп бетү** Тәмам тешләнү. *Менә шул үтмәс пычкылар белән кисеп, тешләнеп беткән балталар белән юнып, кәкре, кыйшык такталардан бәреп-сугып ясаган ояларыбызны --- сыерчык гаиләләре үзара бүлешеп туя алмаслар иде.* А.Хәсәнов

**ТЕШЛӘТТЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тешләтү**. *Аның телен канатканчы тешләттерделәр һәм менә шул тешләнгән теле белән үзен дә утка атачаклар.* Н.Гыйматдинова. *Иман канатларын йолкып, Телен тешләттерделәр, Атын хуҗалыкка алып, Үзен кешнәттерделәр...* Ф.Гыйләҗев

**ТЕШЛӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тешләү**. *«Блудный сын» булып сөйрәлеп йөрү бераз акыл кертә ул, телне дә тешләтә.* Г.Каюмов. *Элек әнә шулай колак тешләтеп ярәштергәннәр.* Р.Кәрами

**Тешләтеп кую** Тиз генә тешләтү; алдан тешләтү. *– Чынлап та, бу балаларны колак тешләтеп куйсагыз, пар күгәрчен шикелле гөрләшеп гомер итәрләр иде, – дип, тегенең башлаган фикерен куәтләп куйды.* М.Яһудин

**ТЕШЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кабып авызда тоту; тешләр белән кысу. *Яулыгын күзләренә төшереп һәм аның почмагын тешләп, ул, башын түбән игән хәлдә, Габдуллага маңгай аша карап торды.* Ә.Фәйзи. *Аннары, ачудан иреннәрен тешләп, еламсыраган кыяфәт белән бабасы янына килә.* Р.Вәлиев

2) Авызга кабып, теш белән өзү, сындыру, аеру. *Габдулла аны [алабутаны] зур ләззәт белән әз-әз генә тешләп алды, анда да берьюлы чәйнәп йотмый, бераз авызында суырып торды.* Ә.Фәйзи. *Мин тиз генә бер кисәген тешләп алдым да калганын этккә бирергә теләгән идем дә, тегe апа: – Инзол, ярамый, ничек оялмыйсың! – дип кычкырмасынмы тегеңәр.* А.Алиш

3) *иск.* Вак-вак кабып ашау. *Кешеләр пивнойларда каткан сухари тешләп утыралар.* Г.Тукай

4) Тешләрне батырып яралау; тешләр белән кысып тоту (хайваннар, җәнлекләр һ.б.ш. тур.). *– Менә бака тешләү шул була ул! – ди әнисе.* Р.Батулла. *Кыз җебеп төшә торганнардан түгел икән. Беләгән шундый итеп тешләде, хәтта Василийның акырган тавышы «Мессершмидт»лар гүелдәвен күмеп китте.* З.Мәхмүди

5) Угын, чагасын, хортумын кадап авырттыру, чагу (бөҗәкләр тур.). *Аның черки дә тешләмәгән килеш үлеп китүе табышмак булды.* Н.Гыйматдинова. *Бар симптомнар, теге бөҗәк тешләп, инде җан тәслим кылырга җыенучыныкы.* И.Кашфразыев

6) *күч.* Чәнчү, кычыттыру, эләктерү (үсемлекләр тур.). *Тигәнәкләр, шайтан таяклары, тагын безне тотып калырга теләгәндәй, чалбар балагын тешли башладылар.* А.Гыйләҗев

7) *күч.* Кырыс һәм каты сүз әйтү. *– Кайберәүләр Тукай булмакчылар!.. – дип [Х.Әюп] тешләп ала.* Ф.Хәсәнова. *Яңа туган бала сәгать саен ашарга сораган кебек, яшь журнал комсызланып материал таләп итә иде. Көннәрдән беркөнне Галиәсгар әйтте: – Карәхмәтне тешләп алмыйсыңмы?* И.Нуруллин

**Тешләп алу** Кинәт тешләү; бераз тешләү. *Чыбыкны тешләп алды бака әфәнде.* М.Гафури. *Йомышчы малай кыярын шарт итеп тешләп алганнан соң чыгып йөгерде.* Г.Бәширов

**Тешләп карау** Тешләп, нәрсәне дә булса ачыклау, белү, төшенү. *Маркс өйрәткәнчә, шик-шөбһә астына алуны файдалырак, куркынычсызрак күргән студент, тешләп карамыйча, бернәрсәгә дә ышанмый.* Т.Галиуллин

**Тешләп кую** Бер тапкыр тешләү; алдан тешләү. *Мин үзем дә Мәгузәнең колагын шушы улым кадәр вакытта тешләп куйган идем.* Н.Яһүдин

**Тешләп тору** Әле, хәзер тешләү

**Тешли башлау** Тешләргә керешү. *Ай үсәсен көн үсеп, берзаманны Кризис өлгереп тә җитте. Үскәч холкы ямanланды бит тегенең. Кешеләрне тешли башлады.* Ф.Имамов

**ТЕШЛӘЧ** *с.* Тешле-тешле, күп тешләре булган

**ТЕШЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тешләү**. *Укыганымда күз алдыма бер сөяк өчен ике этнең тешләшү вакыйгасын китердем.* Ф.Яхин

2) Тешләүчән булу. *Тешләшкән атның артыннан үт, тибешкән атның алдыннан үт.* Мәкаль. *Тешләшү егетлек түгел!* Ш.Фәрхетдин

**Тешләшә башлау** Тешләшергә тотыну. *Гаярь чагы иде Василийның, юбканы икегә генә аерды. Тешләшә башлагач, бер-ике тапкыр йөзенә дә сугып алды.* З.Мәхмүди

**Тешләшеп алу** Бераз гына тешләшү. *Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булырга тиешлеге белән әчтән килешмичә яшәү яшь Мәхмүтне кайчакларда дуамалланып, дөнья белән тешләшеп алырга да этәргәндер...* М.Гали

**ТЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) Тешкә охшаган, тешне хәтерләткән чыгынтысы булган. *Монда бизәкләр савыт-сабага тешле тарак яки үрелгән бау белән төшерелгән.* Г.Дәүләтшин

2) *күч.* Усал телле, телләшүчән. *«Теш тел саклар» – тешле кешенең, ягъни дошманына каршы тора алырлык, үзен яклый алырлык халыкның теле бетмәс, мәгънәсендә.* Р.Батулла

3) Усал, үткен (сүзләр тур.). *Әлеге тешле сорауны бер-ике ел элегрәк юллаган булсагыз, белмим, ниндирәк җавап кайтарыр идек.* Р.Фәйзуллин

**2.** *и. мәгъ.* Усал телле, телләшүчән кеше. *Һәйкәл ташын кимерделәр кайчак Тешлеләрдән күрмәк тешсезләр.* Ә.Баян

**ТЕШЛЕК** *и.* Туку станогындагы кылычның аслы-өсле яңакларының берсе. *Тешлеге какшаган кылыч*

**ТЕШЛЕ ТӘГӘРМӘЧ** *и. тех.* Механизмнарда әйләнмәле хәрәкәтне тапшыра торган чыгынтылы диск формасындагы деталь; йолдызча, шестерня. *Чияле Төп яланында җир сөреп азапланган тракторның арткы тешле тәгәрмәче бик нык баткакланган кара җиргә баткан иде.* З.Зәйнуллин. *Майланган тешле тәгәрмәчләр җулап әйләнеп китте, һәм берниндии интонациясез механик тавыш ишетелде.* А.Азимов

**ТЕШЛЕ́-ТЕЛЛЕ** *с. к.* **телле-тешле**. *Болай Харис кешегә бик ягымлы,*

*тешле-телле түгел, эчми, тартмый.* С.Кальметов

**ТЕШЛЕ́-ТЕШЛЕ** *с.* 1) Кырыйларында керентеләре һәм чыгынтылары булган, телле. *Бу агачларның ботаклары юк, бары тик очларында тешле-тешле яфраклары бар.* А.Алиш

2) Киртләч-киртләч булып торган. *Тешле-тешле кызыл кирпеч дивар. Итәгендә йоклый батырлар.* Г.Афзал. *Тышкы күренеше белән кәлтә еланны хәтерләтә: үзе тәбәнәк, башы зур, сырты тешле-тешле, тарак кебек.* Хайваннар дөньясы

**ТЕШСЕЗ** *с.* 1) Теше төшкән яки бөтенләй үсмәгән (үсми торган). *Менә болары бик катып җитмәгән, тешсез кешегә суырып ятарга әйбәт.* Ф.Яруллин. *Карчык тагын тешсез авызы белән елмаеп куйды.* М.Кәбиров

2) *күч. к.* **тел-тешсез**. *Ул бит еш кына безгә тешсез сатирик әдәбиятыбызны алмаштыра, халык өчен үзенә бертөрле үч алу, «пар чыгару» чарасы булып та хезмәт итә.* А.Тимергалин

**ТЕШСЕЗЛЕК** *и.* 1) Тешсез булу. *Тешсезлек җәфалый, шулхәтле җәфалый ки, кычкырып торып елап җибәрәсе килә.* Г.Кутуй. *Аннан... әле генә тешсезлегеннән көлеп йөргән салам сыйракларны тешләреннән коткаруның мең төрле юлын табар ул!* Р.Рахман

2) Юашлык, карусызлык. *Тешсезлек, мескенләнү шулай дәрәҗәбезне төшерә.* Безнең гәҗит

**ТЕ́Ш ТАБИБЫ** *и. к.* **теш врачы**. *Теш табибына, чынлап та, су буе чират иде.* Д.Булатова. *Теш табибының исемен онытканмын.* Ш.Галиев

**ТЕШ-ТЫРНАК** *җый. и.* Тешләр һәм тырнаклар. *Кылыч сынса – хәнҗәр, хәнҗәр сынса, теш-тырнак бар!* Р.Батулла

◊ **Теше-тырнагы белән** Бөтен көченә, булдыра алган барлык чараларны кулланып. *Мондый чакта кешене фәкать ныклы өмет, тормышка тешең-тырнагың белән ябышу һәм соңгы чиккәчә көрәшә белү сәләте йолып кала торгандыр.* А.Тимергалин. *Буйсынмас өчен, теше-тырнагы белән каршы торды.* М.Хәсәнов

**ТЕШЧӘ** *и. к.* **теш** (*2 – 4 мәгъ.*). *Тәгәрмәч тешчәләре*

**ТЕШЧӘЛЕ** *с.* Тешчәләре булган. *Вак тешчәле йолдызча*

**ТИ** *и. гар.* Иске төрки-татар алфавитында өченче хәреф (гарәпчәдә – та) атамасы. *Мөнирҗан алай гына бирешә торган малаймы соң! – Абый, дим, бисмилланы хәзер үк әйтәм. Менә тыңла: әлпи, ти, си, бисмилләһиррахмәниррахим, – дип, бисмилла әйтергә кереште.* Н.Әхмәдиев. *Сүзлек гарәп графикасының өч хәрефен – әлиф, би, ти хәрефләрен эченә алган.* Ф.Гаффарова

**ТИБӘГӘН** *с.* Тибә, тибешә торган (ат тур.). *Тибәгәнгә тибәрмә, кабаганга кабарма.* Мәкаль

**ТИБӘРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тибәрү**. *Яңадан ул үзен читкә тибәрелгән, кимсетелгән итеп тойды.* Н.Фәттах

2) Этәрелү, тайпылу. --- *тупчылар киртәли торган ут ачтылар. Без дә бөтен кораллардан атабыз. Немец артка тибәрелде.* Х.Камалов

3) *диал.* Нәрсә дә булса үз урыныннан күчерелү, авышу. *Фәргать, «Волга»сына салып, өйләрендә күптәннән бирле бер почмактан икенче почмакка тибәрелеп йөргән «Саратов» суыткычын үзенең дачасына алып килде.* Ф.Яруллин. *Өй җылы булгангамы, кызның юрганы кырыйга тибәрелгән, икегә үргән толымының берсе күкрәгенә төшкән ---.* Н.Әхмәдиев

**Тибәрелә бару** Һаман тибәрелү. *Әйе, еллар уза тора, элекке остазлар, йодрык төйнәп бүгенге тәртипләргә каршы чыга алмаучылар читкә тибәрелә бара.* Л.Хәмидуллин

**Тибәрелә башлау** Тибәрелергә тотыну. *Егерменче гасыр башында инде гарәп-фарсы сүзләренең аңлашылмаганнары көрәш мәйданында җиңелгән солдат кебек читкә тибәрелә башлады.* С.Поварисов

**Тибәрелеп йөрү** Гел тибәрелү. *Хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөргән шагыйрь Нәби Дәүли кайтты. --- Баштарак бераз читкә тибәрелеп йөртелсә дә, --- әдәбиятта урынын-исемен саклап кала алды.* Г.Иделле

**Тибәрелеп килү** Электән, күптәннән хәзерге көнгә кадәр тибәрелү. *Мәгариф өлкәсендә музыка укыту моңарчы Европа системасына корылган иде. Шәрык музыкасы читкә тибәрелеп килде, санга сугылмады.* Г.Ахунов. *Ләкин коммунистлар алдатмый, армия яше җитү белән, моңарчы комсомолдан читкә тибәрелеп килгән берән-сәрән егетләрне ашыгыч рәвештә яшьләрнең бу оешмасына тарталар.* Безнең гәҗит

**Тибәрелеп тору** Шактый вакыт тибәрелү. *Әдәбиятка ул [Ә.Еники], күргәнебезчә, кыенлык белән керде. Хәтсез еллар читкә тибәрелеп торды.* Ф.Хатипов

**ТИБӘРҮ** *ф.* 1) Тибү, этеп җибәрү. *Ләгәнне аягы белән тибәрде, һәм шул мәлдә башына бер уй килде: шикаять язарга кирәк ләбаса!* М.Хуҗин

2) Читкә этәрү, урыныннан арырак шудыру. *Краснов, йодрыкларын йомарлап, олаучыга ташланмакчы итеп талпынды. Арага озын егет керде. Кулларын кире тибәреп, урынына утыртты.* Х.Камалов. *Фараларның --- яктылык көлтәләре караңгылыкны як-якка тибәреп үтә.* Р.Төхфәтуллин

3) *диал.* Төртеп җибәрү, тиз генә этәреп кую. *Зәйни финның штыгын үзенеке белән читкә тибәрде.* З.Зәйнуллин. *Шәйхи тегенең тибәрүеннән өстәлгә чигенеп бәрелде, өстәл өстендәге бер чүлмәк сөт идәнгә төшеп түгелде.* И.Туктар

4) *күч.* Читләштерү, үз итмәү; йөз чөерү. *Чынлыкта мин, Шамилне үземнән тибәреп, ялгышлык кына эшләдем шикелле ---.* Ә.Баян. *Сыер --- маңгаенда уч төбе кадәрле агы булган кара бозавын үги итте: яламады, кырыена килмәде, бусы минеке түгелдер моның, дигән сыман гел читкә тибәрде.* Ф.Яруллин

**Тибәрә башлау** Тибәрергә тотыну. *Өлкәннәрдән күрмәкче, Эмма да аны читкә тибәрә башлый: абыйсына җикеренә, йодрык белән ташлана.* Ә.Маликов. *Садагын, шакылдавыгын читкә куеп, хәнҗәрен алды да иплән кенә туфракны читкә тибәрә башлады.* Л.Зөлкарнәй

**Тибәрә тору** Озак тибәрү, әлегә тибәрү белән шөгыльләнү. *Каз мамыгыдай йомшак карны бергәләшеп чабаталарыбыз белән як-якка тибәрә торгач, янып бетмәгән дәү бер кисәүгә, дөресрәге, бүрәнә башына юлыктык.* К.Миңлебаев

**Тибәрә төшү** Бераз тибәрү; тагын да ныграк тибәрү. *Шәйдүк бурканың ачык ягына капланган чыптаны тибәрә төште дә болытларга карады.* К.Нәҗми

**Тибәреп бару** Берәм-берәм, рәттән тибәрү. *«Татарга куркыныч күз белән караган» Россия феодаль монархиясе, сүз дә юк, мәдәни омтылышларны да --- читкә тибәреп барды.* Ф.Галимуллин

**Тибәреп җибәрү** Кинәт тибәрү, тиз арада тибәрергә дә өлгерү. *Әле ярый алыплар сабыр, беркайчан да җир өсте кешеләре кебек: «Йөдәтеп тормасана!» – дип тибәреп җибәрмиләр.* Ш.Алпар

**Тибәреп кую** Кинәт, көтмәгәндә тибәрү; бер тапкыр тибәрү. *Тик бу юлы да каршысында басып торган ефрейтор артык онытылырга ирек бирмәде, җилкәсе белән читкә тибәреп куйды* ---. Р.Мөхәммәдиев

**Тибәреп ташлау** *сөйл.* Тиз генә, кисәк кызулык белән тибәрү. *Самолёт янына килеп, аның тәгәрмәч алларына куйган тормоз колодкаларын читкә тибәреп ташладым да кабинага сикереп менеп утырдым.* С.Баттал. *Исмат аны --- Нәкыя кочагын дәгъвалаучы дип аңлаган. Билгеле, үзенең татлы калҗасына үрелгәнне ул бар көче белән тибәреп ташлый.* Х.Камалов

**Тибәреп тору** Бертуктаусыз, гел, һәрвакыт тибәрү. *Мучирмәнең сай һәм тымызык суын авыл елгасы, үзенә ияртәсе килмәгәндәй, кирегә тибәреп тора.* М.Хуҗин

**ТИБӘТ** *и. диал.* Бәби өчен махсус күлмәк; бәби төрү өчен әзерләнгән тукыма кисәге. *Тибәткә төреп салу*

**ТИБЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тибү**. *Бик тиз аңлап алдым: Чуар колак эше бу. Әнә аның тырнак эзләре, шунда ук тибелеп, өелеп калган кар өемнәре.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Җәберләнү, читкә этәрелү. *Ни күрсә дә монда күрде Башкортстан татарлары. Сибелде дә, тибелде дә, Кем дип кенә аталмады.* Р.Миңнуллин. *Вафинны райком яклый, милиция – кулында: кем каршы әйтә, шул читкә тибелә, кем яный, шул каталажкага озатыла.* Р.Камал

**Тибелеп йөрү** Гел тибелү. *Тишек кәвеш сыман теләсә кая тибелеп йөргән Ярослав Юрийның малайлары Всеволод белән Инварны котырткан да бөек кенәзне теге дөньяга озатмакчы икән.* В.Имамов

**Тибелеп тору** Гел, һәрвакыт тибелү

**ТИБЕН** I *и.* 1) Елганың кайбер урыннарында (гадәттә яр кырыенда) була торган кире агым

2) *к.* **типкен** II

**ТИБЕН** II *и.* Терлекнең (башлыча атларның) кышкы көтүлеге, кар катламын тибеп актарып, кар астындагы үләнне ашап йөрү урыны. *Аркасына ияр салып ает тартуга да гаҗәпсенмәде: «Тибендә кунган җылкы көтүендә берәр хәл бардыр, яисә кышлауга бүре килгәндер дә шуны куарга чыгалардыр», – дип уйлады.* Г.Ибраһимов. *Себер күчмәннәре гадәтенчә, атлар тибенендә тукланганнар, ягъни, гадәттә, бик калын булмаган карны тояклары белән ишереп, кар астындагы үләнне ашаганнар.* Р.Әхмәтьянов

**ТИБЕНГЕ** I *и.* Ияр астына салына торган күн япма; тукым, чапрак. *Чуар атын бер типте, Тибенгедән тир чыкты* ---. Дастан. *Арка авылның утыннан Ат утлаткан бар микән? Тибенгесен тирләтеп Төнлә юрткан бар микән?* Н.Исәнбәт

**ТИБЕНГЕ** II *и.* Әтәч һәм башка кайбер кошларның аякларында яки канатларында була торган, тырнакка охшаган мөгезсыман очлы үсенте; *русчасы*: **шпора**. *Кайбер кошлар тибенгеләре ярдәмендә дошманнарыннан саклана*

**ТИБЕНГЕ** III *и. к.* **тибен** II. *Ә йот елында исә җепшеклектән соң кинәт суытып, даланы бозлавык каплый. Тибенгедә йөргән маллар, ашарлары-на үлән таба алмыйча, аякларын суза.* Р.Зәйдулла

**ТИБЕНЛЕК** *и. к.* **тибен** II. *Тибенлеккә килеп чыксалар, карт айгыр белән теге хәлсез яшь тай сугыша: тибешәләр, тешләшәләр, күкрәккә күкрәк бәрешәләр – кем җиңәрдән инде!* Г.Якупова

**ТИБЕНҮ** *ф.* 1) Бер урында кабаткабат тибеп тору, бертуктаусыз тибү. *Туры бия нигәдер тынычсызлана, бәйләгән дилбегәсеннән ычкынырга теләп як-якка тартыла, аякларын җиргә бәреп тибенә иде.* Г.Галиев

2) Вакыт-вакыт, еш-еш типкәләү. *Сөйгәне белән кавышканда һәм карынында бала тибенгәндә, үзен мәңгелек дип хис итә адәм баласы.* М.Мәһдиев. *Рәхимҗан абый Акбәкәлне сыерга кушып карамакчы иде – сыер имезмәде, тибенде.* Ф.Яруллин

3) Тояклары яки тырнаклары белән җирне, туфракны, чүп яисә тизәк өемнәрен типкәләп, актарып азык, җим эзләү. *Чебешләр капка астыннан урамга сибелделәр. Черкелдәп-черкелдәп, җим эзләп тибенделәр.* А.Алиш. --- *бераз вакыт Сары тавык җилфердәп торган озын купшы койрыклы, зур кызыл кикрикле әтәч тирәсендә, бүтән тавыклар тирәсендә тибенде* ---. Н.Фәттах

4) *күч.* Тузыну, дулау, ярсу. *Усал хуҗа сүгенеп тибенә: «Һи, булдыксыз, теләмсәк, расчёт бирәм!»* Г.Кутуй. *Зәмзәмбикә аны торгызмакчы була, тегесе яман сүгенеп аңа тибенә.* Н.Фәттах // Ачулану, орышу; гайрәтләнү. *Бервакыт Гөлбикә Халикъка каты гына тибенеп куйды.* Ш.Камал. *– Ай! – Һайт! – Зәбир үзенең ничек кычкырып җибәрүен сизми дә калды. Кыз исә һаман тибенде, һаман кычкырды.* Г.Гыйльманов

**Тибенә башлау** Тибенергә тотыну. *Каткан бияләйле йодрыгы белән селтәнә, тыпырчынып тибенә башлады.* Л.Ихсанова. *Бала инде ярыйсы ук тибенә башлаган иде* ---. М.Кәбиров

**Тибенеп алу** Бераз тибенү. *Менә шул Кентавр кайчакларда араннарны җимереп тә чыга, ярсып тибенеп тә ала* ---. М.Галиев. *[Тавык] Ихтыярның каккан казык кебек бер урында тик торуын күргәч, салмак кына --- китеп барды. «Тавык сөендерерлек әйберең дә булмагач, ник кайтып йөрдең монда?» дигән сыман --- чүп-чар туздырып тибенеп алды.* Р.Вәлиев

**Тибенеп җибәрү** Билгеле бер моментта тибенү; кисәк тибенү. *Бия тибенеп җибәрә дә, бөҗәкләрнең бер өлеше очып китә.* Р.Сәгъди. --- *айгыр тынычланып ашый башлауга, тагын тегенең койрыгыннан берничә кыл йолкыды. Кара айгыр бу юлы кушаяклап тибенеп җибәрде.* Ф.Яруллин

**Тибенеп кую** Кинәт кенә, бер тапкыр тибенү. *Шулчак карынындагы икенче җан, үзенең барлыгын белгертеп, тибенеп куйды.* Х.Камалов. *Таштимерова тузгыган чәчләре астыннан ачулы карады да, нык кына итеп, аягы белән тибенеп куйды.* М.Маликова

**Тибенеп тору** Бертуктаусыз яки хәзерге моментта тибенү. *Кигәвеннәр өереннән тәкате калмаган ат юл уңаендагы инешкә борып алып кереп китте, атлаган уңайга тибенә торгач, арт аягы бавыргалыкка эләкте.* Ж.Дәрзаман. *Баксаң, якында гына бер кызый, чыелдап кычкыра-кычкыра, җиргә тибенеп тора...* Г.Гыйльманов

**Тибенеп яту** *сөйл.* Шушы мизгелдә, әле, хәзер тибенү. *Тирестә тибенеп яткан сары тавык, үзенә таба якынлашып килгән коточкыч нәрсәне күреп, куркып, бакча киртәсенә таба йөгерергә тотынды.* Н.Фәттах

**ТИБЕРЧЕНҮ** *ф.* 1) Аякларны өскә күтәргән хәлдә тәртипсез рәвештә тибү хәрәкәтләре ясау. *Ул, аш яныннан торып, караватта тиберченеп яткан имчәк баласын алды һәм аны имезергә тотынды.* Ә.Галиев. *Кытыкланган малай шаркылдап көлергә, тиберченергә тотынды.* Т.Әйди

2) *диал.* Тыпырчыну

**Тиберченә башлау** Тиберченергә тотыну. *--- дуңгызны яткырып, муенына пычакны куйганда, аның тиберченә башлаганын күргәч тә, ишәк баласы, качып, анасы янына килде ---.* К.Насыйри. *Югыйсә кызның күзләре аның хәтерендә шундый ачык һәм тере, аны күз алдына китерүгә, йөрәге тиберченә башлый...* Ә.Дусайлы

**Тиберченеп алу** Бераз, аз гына вакыт тиберченү. *Тиберченеп ала нәни колын.* Р.Низамиев

**Тиберченеп карау** Сынау өчен тиберченү. *Кыз тагын тиберченеп карый.* Ә.Дусайлы

**Тиберченеп тору** Әле, хәзер, күз алдында тиберченү; даими, һәрвакыт тиберченү. *Бәби гел тынычсызланды, тиберченеп торды*

**ТИБЕТ** *и.* Тибет таулыгы тирәсендә яшәүче төп халыкның теле. *Сөйләшерлек дәрәҗәдә булса да тибет телен өйрәнә һәм берничә елын Һималайга сәяхәт кылуга багышлый.* М.Галиев. *Дөяләр көтәргә дә күнекте ул, тибет телен дә өйрәнеп алды ---.* З.Мурсиев

**ТИБЕТЛЫ** *и.* Үзәк Азиядә Кытайның Тибет автономияле районында яши торган буддизм динендәге төп халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Бу хыялый «сугыш» төркиләрдә камлау яки камау дип, монголларда, тибетлыларда чам --- дип аталган.* Р.Әхмәтьянов. *Төркиядә һәм Гыйракта – көрдләр, Кытайда тибетлылар һәм төркиләр мәсьәләсе хәл ителмәгән.* Р.Хәкимов

**ТИБЕ́ТЧА** *рәв.* Тибет милләтенә хас булганча, алардагыча итеп; тибет телендә. *Казаннан тибетча дәвалаучы табиблар килә, дигән белдерү дә басылган газетада.* Хезмәт даны

**ТИБЕШ** *и.* **1.** 1) Йөрәкнең һәм кан тамырларындагы канның ритмлы хәрәкәте. *Ул --- колагын Ирекнең күкрәгенә якынайтты, ләкин йөрәкнең тибешен сизмәде.* Ф.Садриев. *Шәфкать туташы, читкәрәк күчеп утырып, Сәетнең кан тибешен саный башлады.* Т.Галиуллин

2) Берәр ноктадан ыргылып яки берәр урында хәрәкәт иткән җисемнең нинди дә булса таяныч ноктасына ясаган басымы, бәрүе. *[Митричевның] җиргә таянган куллары пулемёт аткан тибеш белән дерелдиләр.* Г.Бәширов. *Карында беренче мәртәбә зәгыйфь кенә тибеш барлыгын тойган сәгатьтән башлап, ана йөрәгенә шом төшә.* Г.Ахунов

3) *күч.* Көчле агым булып астан өскә бәреп чыккан суның басымы, көче. *--- ул чишмә авызыннан эчәргә теләп иелсә, аның сулышы тиюгә, су тибеше әкренли, юынырга керешсә, тына, туктала.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Ритмик агыш. *Шулай итеп әнкә бармакларындагы моң тибеше тальян аша улы бармакларына күчкән.* М.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, кызу. *Картның башы тибеш эшли икән, шундук кемнәргәдер ым кагарга да өлгерде.* Ф.Хөсни. *Шулчак өйдә авырып калган анасы, ач туганнары сабыйның исенә төште, ул тибешрәк атлый башлады.* Р.Батулла

**ТИБЕШКӘК** *с.* Тибүчән, тибешә торган гадәте булган. *Мүкләк сыер сөзешкәк, аксак бия тибешкәк.* Әйтем. *Булган ишәк Бик тибешкәк. Һәркем аны Читләп үткән.* Ш.Галиев

**ТИБЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тибү**. *Атлар тибешкәндә, арада ишәкләр таптала.* Әйтем

2) Тибү; тибә торган гадәте булу. *Ә син ат кебек тибешә беләсеңме?* Ә.Фәйзи. *Бүреләр бит беренче чиратта көтүдәге --- чирләшкәрәк затларны аяктан ега, бугазлый. Дошманнарыннан тибешеп, тешләшеп --- котыла алучыларның балалары да зирәгрәк, зиһенлерәк, үткенрәк була.* А.Хәсәнов

**Тибешә башлау** Тибешергә тотыну. *Чынлап та, кола айгыр иясен аңлый иде булса кирәк, чөнки янына башка берәүне дә җибәрмәс иде. Я тешләргә ташланыр, я тибешә башлар.* М.Хәбибуллин. *Карынындагы баласы тибешә башлагач кына белде ул үзенең йөкле икәнен.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Тибешеп алу** Бераз, аз гына тибешү. *Кайберләре, шушы киң аланга да сыеша алмыйча, берсен берсе куарга, тешләшергә тотыналар, бик яман чинашып, тибешеп алалар.* Г.Бәширов. *Ара-тирә яшь тайлар тешләшеп яки тибешеп ала ---.* Ф.Садриев

**Тибешеп китү** Кинәт, көтмәгәндә, уйламаганда тибешә башлау. *Алар уттай көйдергән кояш астында әлсерәшеп торсалар да, көтмәгәндә шартшорт тибешеп китәләр, ә кайвакыт, бәйләүдә килеш аллары белән сикерә алмаганга күрә, артларын һавага чөешәләр --- иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тибешеп кую** Кисәк тибешү; аратирә тибешү

**Тибешеп тору** Даими, һәрвакыт тибешү; әле, хәзер, шушы мизгелдә тибешү

**Тибешеп яту** *сөйл. к.* **тибешеп тору**. *Кап-кара түтәл өстендә тибешеп яткан тавык чебиләрен күргәч тә, эшнең нидә икәнен аңлаган оныклары Булат: – Их, зур әти, кемнәр шулкадәр мыскыл итте кыярны? – дип, --- әрлебирле йөренде.* А.Хәйртдинова

**ТИБРӘЛДЕРҮ** *ф.* 1) Селкү, селкетү; калтырату, чайкалдыру. *Эрбетләрнең*

*ботак-ылысларын Тибрәлдереп, таган иттереп, Уйнаклатып елтыр койрыкларын, Борындыклар йөри сикереп.* К.Булатова. *Туган йортка кайтып кына була! Тагын ничә йортың булса да. Монда мине тибрәлдергән бишек, Тәпи атлап чыккан бусага.* Ш.Җиһангирова

2) Җиңелчә генә селкетү, кагу. *Ап-ак чиләкләрен тибрәлдереп чишмәдән кайтып килүче Гөлйөзем басма уртасында туктап калды.* Р.Бәшәр. *Укытучы апаның кап-кара калын озын толымнарын тибрәлдереп өй каршыннан үтеп китүләрен --- сокланып карап калабыз.* Ф.Җамалетдинова

3) *күч.* Дулкынландыру (тавыш, сөйләү, җыр тур.). *Бу көй, су өстендә чайкалган дулкыннар шикелле, синең җаныңны әле йомшак кына рәхәттә тибрәлдерә ---.* Г.Бәширов. *Тасмаларга язган җырларың, Яңгырасыннар алар төсең булып, Тибрәлдереп йөрәк кылларын!* М.Сәгъдиев

**Тибрәлдереп алу** Азга гына, бернисә вакытка гына тибрәлдерү. *Борынгы моң, чорлар аръягында Талгын гына тибрәлдереп ала Моң агышын көмеш бырсгының.* Ф.Гыйззәтуллина

**Тибрәлдереп кую** Бер мәртәбә тибрәлдерү. --- *эчемлек бугазы буйлап аска төшә, акрын гына гәүдәсенә җылы тарала, дулкын булып баш миенә килеп бәрелә, күзләре ачылып, айнып киткән кебек була, рәхәт тибрәлдереп куя.* Х.Мөдәррисова

**ТИБРӘЛҮ** *ф.* 1) Тибрәнү, тирбәнү, бер ритмга җиңелчә селкенү. *Без дә салмак кына юырттырып, тибрәлеп кенә барабыз.* Ә.Еники. *Арышлар чайкала-чайкала серкә очыра. --- тилгәннәр --- һава дулкынында җәй белән генә тибрәләләр.* М.Мәһдиев

2) Тирбәнү, дулкынлану, чайкалу. *Арышлар өстеннән йөгерешкән тасма дулкыннар Зәбидәнең яшькелт яулыгыдай тибрәлә.* Н.Хәсәнов. *Дулкыннарда тибрәлгән ак пароходтагы үткен зәңгәр күзле ир-егетнең баш очыннан Зуфирәгә таба юл салды микән әллә ул?* М.Маликова

**Тибрәлә башлау** Тибрәлергә тотыну. *Яшел уҗым диңгез булып җилдә тибрәлә башлады.* Ф.Яхин. *Тиздән кәбестә түтәлләре өстендә көтүләре белән ак күбәләкләр тибрәлә башлар.* Ватаным Татарстан

**Тибрәлеп алу** Бераз гына тибрәлү. *Нәрсә бу? Гашыйк булумы, әллә булмаса, яшьлектәге бер хис дулкынында тибрәлеп алу гынамы?..* М.Хәбибуллин. *Дугаланып бөгелгән озынча керфекләре салмак кына тибрәлеп алды ---.* Н.Хәсәнов

**Тибрәлеп китү** Кинәт, нииндидер сәбәптән тибрәлү. *Килен янына басып эшләгән әбинең әле дә шәльяулыгы тибрәлеп китә күк.* Н.Хәсәнов. *«Дазар» дигән нииндидер сәер исемне укыгач, аяк астында идән тибрәлеп киткәндәй тоелды.* А.Әхмәтгалиева

**Тибрәлеп кую** Кинәттән тибрәлгән хәрәкәт ясау. *Кызның кашлары тибрәлеп куйды ---.* Х.Камалов. *Малай шулай дип уйлап өлгермәде, ак челтәр пәрдәләр тибрәлеп куйды ---.* Ф.Бәйрәмова

**Тибрәлеп тору** Әле, хәзер, күз алдында тибрәлү; даими, һәрвакыт тибрәлү. *Кинәт аның --- күз аллары караңгыланды, дулкында тибрәлеп торган көймә кебек чайкалып торды да бөтен гәүдәсе белән идәнгә ауды.* Г.Галиев. *Өйдә коточкыч дым тибрәлеп тора, һәм тонык караңгылык.* Ф.Җамалетдинова

**ТИБРӘНЕШ** *и.* Чайкалу, талгын гына селкенү, селкенгәләү хәрәкәте; вибрация. *Газизҗанның башы бераз гына артка чөелгән, кашлары, керфекләре, йөзендәге җыерчыклары әллә нинди тибрәнешләр ясыйлар, күзләре, моң чишмәсенең типкән урынын ычкындырмаска теләгәндәй, яртылаш йомылганнар.* Ф.Садриев. *Аваз һәм моң тибрәнешләрен эчтән тоеп җырлаганга, Хәлимнең тавышы көчәйгәннән-көчәя барды.* Ф.Яхин

**ТИБРӘНҮ** *ф.* 1) Җиңелчә генә җилфердәп, селкенеп тору, чайкалу. --- *сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә.* Ә.Еники. *Үлән сабаклары --- Әмирнең ботларына, кулларына орынып, җилдә тибрәнә.* Г.Нургатина

2) Җиңелчә һәм еш-еш хәрәкәт итү. *Тибрәнә керфек --- ым бирә, өн бирә әкрен генә.* Ш.Бабич. *Йөзе ут кебек яна, күкрәге тибрәнә, ә күзләре чиксез сөенечле бәхет белән тулы.* Г.Әпсәләмов. *Кайнар иреннәр пышылдап тибрәнде.* Г.Сәгъди

3) Җиңелчә генә дулкынлану. --- *үләннәр юеш, ямь-яшел, чәчәкләрдә энҗе бөртегедәй түгәрәк тамчылар җемелди, Түреш өстендә ефәктәй юка гына ак томан тибрәнә.* Ә.Еники. *Ай нурын чагылдырып, дулкыннар тибрәнә, алар әйтерсең җанлылар, әйтерсең аларның өстенә көмеш сибелгән.* Г.Әпсәләмов

4) Тартылып, чиртенеп калтырау. *Уңайлап алды кулга думбрасын, Кереште, уйный ул; тибрәнде кыллар, Сузылды кебек болында зарлы моңнар.* Ф.Бурнаш. *Мандолина кыллары тибрәнде*

5) Талпыну, җилпенү. *Күкеле сәгать башында күке тибрәнеп кычкыра.* Д.Аппакова. *Сабан тургаемы – зәңгәр хозурлыктагы бишектә тибрәнә-тибрәнә моңланырга кереште...* Р.Мөхәммәдиев

6) Кузгалу, бер мәртәбә генә селкенеп кую. *Шуларны әйтергә уйлаган иде Нина Андреевна генералга, теле тибрәнде, сүзе чыкмады, зур командир алдында акланып маташуның әдәпсезлек икәнен яхшы аңлый ул.* С.Поварисов

7) *күч.* Җиңелчә калтырап ишетелү. *Куллары як-якка җәелде, һәм карлыккан тавышы эчке бер дулкынлану белән тибрәнде: – Кызым!* Н.Хәсәнов. *Күңелнең иң тирән бер җирендә яшеренеп яткан милли көйләр тибрәнә ---.* Ф.Вәлиев

8) *күч.* Көчле яки нечкә хис тәэсиренә бирелеп китү, сулкылдау (йөрәк, һ.б. тур.). *Аһ, бу йөрәк ник тибрәнә, ник талпына?* К.Тинчурин. *Ул чиксез кодрәткә ия, дәртле дә, сагышлы да кабатланмас җыр җанга тансык кебек, канат бирә, аның агышларына кушылып, күңел тибрәнә, күптән көткәннәргә сусау, ярату арта.* Н.Хәсәнов

**Тибрәнә башлау** Тибрәнергә тотыну. *Минә өй эчендә аның басынкы моңы тибрәнә башлады* ---. Г.Бәширов. *Гөлҗиһанның битләренә ут капты, керфек очларында яшьләре тагы тибрәнә башлады.* Ф.Бәйрәмова

**Тибрәнеп алу** Кинәттән, аз гына тибрәнү. *Кайчак трамвай дугасыннан*

*кабынган яшькелт чаткының яктысы палатага кереп, шәрә стеналарда тибрәнеп ала.* Г.Әпсәләмов. *Аның озын, матур керфекләре ниндидер сихри ритмда тибрәнеп алдылар да ачылып киттеләр.* Г.Гыйльманов

**Тибрәнеп карау** Сынау өчен тибрәнү. *Ясап бетергәннән соң, Унөч әйтә: – Беләсеңме, Унөч синнән куәтлерәк бит. Син кереп тибрәнеп кара әле. Сиңа түзмәсә, Унөчкә түзми дә түзми инде ул, – ди.* Әкият

**Тибрәнеп кую** Кинәттән тибрәнгән хәрәкәт ясау. *Хөсәеннең кинәт ниндидер йөрәк тамыры тибрәнеп куйгандай булды.* А.Расих. *Хәлилнең йөзе яктырып китте, керфекләре, күңеле тулган кешенеке шикелле, тибрәнеп-тибрәнеп куйды.* Ф.Садриев

**Тибрәнеп тору** Тибрәнгән хәлдә булу, туктаусыз тибрәнү. *Авыл янында гына су тибрәнеп тора.* Г.Әпсәләмов. *Соңгы төндә дә авыл тальян моңы, яшьләр җыры дулкыны агышында тибрәнеп торды.* С.Поварисов

**ТИБРӘТКЕЧ** *и. тех.* Төрле калтырау, электр дулкыннары һ.б.ш. тирбәнешләр барлыкка китерә торган прибор, механизм, җайланма; вибратор

**ТИБРӘТҮ** *ф.* 1) Тибрәлдерү, селкетү; калтырату, чайкалдыру. *Җил чак кына тибрәтте исә, шау чәчәккә күмелгән алан буйлатып төрле төстәге дулкыннар чабышып үтә, алар өстендә уенчык җилкән шикелле күбәләкләр чайкала иде.* А.Тимергалин. --- *Фәргать кечкенә вакытта, әбисе аны кабык арбага салып, шушы көйгә тибрәтә иде.* Ф.Бәйрәмова

2) Җиңелчә һәм еш-еш хәрәкәт иттерү, кыймылдату. *Кыз сискәнгәндәй, керфекләрен тибрәтеп, Зөфәргә бер карап алды.* Ә.Еники. *Җәмилә Закировнаның сөйләшерлек хәле калмаган иде, ак җәймә өстендә үтә күренмәле булып тоелган бармакларын тибрәтеп кенә ишарә ясады ---.* М.Маликова

3) *күч.* Кузгату, дулкынландыру. *Мондый минутларда кешенең уйлары да, тойгылары да, --- ничектер, үзенә бертөрле – үтә пакь, үтә кадерле була, алар күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә.* Г.Әпсәләмов. *Басу, күк йөзе, кат-кат ерак офыклар моң тибрәтә ---.* М.Мәһдиев

**Тибрәтә башлау** Тибрәтергә тотыну. *Зур-зур дулкыннар безнең пароходчыкны сикертә, тибрәтә башладылар.* Ф.Әмирхан. *Роботулладан көнләшеп, мин үзем дә соңгы айда каләм тибрәтә башладым.* А.Тимергалин

**Тибрәтеп алу** Кинәт, аз гына тибрәтү. *Әһлетдин бабай --- пычкысын тибрәтеп алды, Асия кулындагы гармунга карап мут кына елмайды.* Г.Әпсәләмов. *Бу юлы да күз кабакларын челт-челт тибрәтеп алды да тезеп китте ---.* Н.Хәсәнов

**Тибрәтеп җибәрү** Кинәт тибрәтү. --- *ул пычкының бер башын скрипка кебек аяк астына кыстырып, икенчесеннән шундый тибрәтеп җибәрде: гади пычкы сандугач кебек сайрый башламасынмы!* Г.Әпсәләмов. *Әмма Габделбәр авызыннан чыккан Йөзембикә исеме аның күңел кылларын тибрәтеп җибәрде.* Г.Нурулла

**Тибрәтеп карау** Сынау өчен тибрәтү. *Моңарчы, шигырь язам дип, бер мәртәбә дә каләм тибрәтеп карамагангадыр, мөгаен.* Ә.Сафиуллин. *Шунлыктан ул, коры сүз биреп, ничек тә бу хакта егетнең күңел кылларын тибрәтеп карарга, кирәк икән, намусын үгетләргә дә ниятләп куйды.* Ф.Яхин

**Тибрәтеп кую** Бер мәртәбә тибрәтү. *Кыз, «әйе, бу мин» дигәндәй, керфек тибрәтеп кенә куйды.* А.Әхмәтгалиева. *Җылы һава агымы килеп бәрелгән саен, тигәнәкләр әкрен генә авыр башларын тибрәтеп куялар.* Ф.Җамалетдинова

**Тибрәтеп тору** Әле, хәзер, күз алдында тибрәтү; һәрвакыт, туктаусыз тибрәтү. *Шулай да беренче тапкыр өемә килеп җырлаган Рафаэль Ильясов һаман күңел дулкыннарын тибрәтеп тора сыман.* Ф.Яруллин. *Беркемгә дә, тибрәтеп торырга дип, бишек асып куймаганнар.* Ф.Җамалетдинова

**ТИБРӘ́Ү** *ф.* 1) *диал.* Селкенү; калтырау, чайкалу. *И әремнәр тибри талгын җилдән, Иркәләнә җаннар бик соңлап.* Р.Әхмәтҗан

2) *күч. к.* **тибрәтү** (*3 мәгъ.*). *Күңелләрне тирән хисләр тибри.* М.Гаяз

**ТИБҮ** I *ф.* 1) Җиргә яки башка берәр нәрсәгә аякны селтәп бәрү, аяк белән ору. *Шул мизгелдә үк Кави артыннан килгән Усманов хром итеге белән тоткынның авызына китереп тибә: – Сволочь!* З.Зәйнуллин. *Флүн кәләшен тоткан, үзе ялтыравык кара ботинкасы белән тюльпаннарга тибә, аларны читкә этәрергә азаплана, ә чәчкәләр типкән саен, авыртудан сискәнгәндәй, тетрәнәләр ---.* М.Маликова

2) Һөҗүм итеп яки үз-үзен саклап, аяклары белән ору, бәрү (хайван тур). *Ат, бичара, нишләргә белмичә бер артка чигенә, бер алга тартыла, койрыгын бертуктаусыз уңга-сулга селти, дүрт аягы белән дә алмаш-тилмәш корсагына тибә иде.* Ә.Еники. *Яшь тай бераз иркәләнеп торды да, яман каты кешнәп, тоягы белән җиргә типте ---.* Р.Батулла

3) Нәрсәне дә булса аяк белән тибәреп уйнау. *Оныталмыйммы Иркен стадионда Йөгерә-йөгерә футбол тибүне.* М.Җәлил. *Кем балык тота, кем җиләк җыеп килә, кем черем итә, кем туп тибә я шахмат уйный.* Р.Фәйзуллин

4) Тояклары яки тырнаклары белән җирне, туфракны һ.б.ш.ны типкәләп, актарып азык, җим эзләү; тибенү. *Илгә җот килде, тибеп ашарга мөмкин булмаганга, малның бик күбе һәлак булды.* Г.Ибраһимов. *Теңкәгә тиде шул сары тавык: бакчага керә, түтәлләрне тибә.* Н.Фәттах

5) Сулкылдау, ритмлы хәрәкәт ясау. *Авыру хәрәкәтсез ята. Ләкин йөрәге эшли, тамыры тибә, сулышы тигез.* Г.Әпсәләмов. *Алда булачак авыр хәлләрне күз алдына китереп, йөрәк сулыксулык тибә, әрнеп әчетә, бәгырьне телем-телем кыеп ала.* Х.Камалов

6) Тәндә, тиредә күзгә күренә торган нинди дә булса үзгәреш барлыкка килү, берәр нәрсә өскә бәреп чыгу. *Тугаевны күргәч, каушады, кинәт төсе китте, иреннәре күгәрде, борынының ике ягына кызгылт таплар типте.* Х.Камалов. *Яңа гына мыек тибә башлаган яшь чырайлы бу малайларның бүген-иртәгә ут эченә барып керәчәгенә ышану бик кыен иде.* М.Мәһдиев. *Маңгаена тир*

*типте*. Т.Галиуллин // Гомумән астан килеп чыгу; үсеп чыгу. *Юл читендә чирәм типкән*

7) Ерткыч яки ау кошлары югарыдан, һавадан һөҗүм итеп корбанын эләктерү. *Агыйделкәйләрнең балыгы уяу, Акчарлаклар тибеп ала алмый*. Җыр. *Газинур исә, шатлыгын яшерә алмыйча: – Фашистны бәреп төшерделәр! Нәкъ карчыга сыман типте! – диде*. Г.Әпсәләмов

8) Басым белән бәреп чыгу. *Шәрәфи --- самавырдан чыккан парны, шул парның бик зур көч белән һавага тибүен күрде*. Т.Госман. *Маңгаенда сыдырылган җирдән кан тибә*. Ф.Садриев. *Габдерәшит карт, учы белән алып, суны кабып та карады: суы әйбәт, ят тәм юк, үзе салкын иде. Димәк, чишмәсе тибә*. Н.Гыйматдинова

9) Һөҗүмгә, кысуга, басымга каршы көч белән җавап кайтару. *Ашыгыч оборона оештырып, барлык контратакаларны кире тибәргә!* И.Гази

10) *иск. к.* **типтерү** (*2 мәгъ.*). *Кулга акча төшкәндә, рәхәтләнеп тибеп, бераз күңел юатып калмасак, башка һичбер шатланыр урыныбыз юк*. Г.Камал. *Авылда унбиш көн тордым, никрутлар тибәләр генә*. Г.Ибраһимов

11) *күч. гади с.* Урлау, чәлдерү, шудыру. *Кычыткан белән ярды күрше бабай Төпсез ыштанны да салдырып: Күкәй типкән идем*. Г.Афзал. *Бер атна да узмаган, атны караклар типте дип, гариза илтеп биргән*. Х.Камалов

12) *күч. к.* **тибәрү** (*4 мәгъ.*). *Бертуганың чит тибәдер Дәүләт тигез булмаса*. Дәрдемәнд. *Бераздан өлкә комитетында тагын секретарь алышынды. Үз урынын югалтудан куркып, Усманов Беляевны читкә типте*. М.Вәлиев

◊ **Тибеп очыру** 1) Бик каты тибеп шактый еракка җибәрү; егу, аудару, мәтәлдерү. *Кәефе шәптән түгел бугай, никтер, ордым-бәрдем йөри, аяк астында буталган ялагай мәчене ачу белән тибеп очырды*. С.Сабиров. *Камилнең әтисе, аяк астына туры килгән урындыкларны тибеп очырып, урамга атылды ---*. Ф.Бәйрәмова; 2) Бәреп төшерү (хөкүмәтне һ.б.ны). **Тибеп ташлау** *к.* **тибеп очыру**. *Шашынган буржуазияне хөкүмәт башыннан тибеп ташларга торыгыз!* И.Гази. **Тибеп ыргыту** *к.* **тибеп очыру**. **Типкән саен** Адым саен, бик еш очрау, күп булу турында. *Аертып өйләнергә йөрмисеңме тагын? Типкән саен алма кебек кызлар бар чакта!* Ш.Хөсәенов. *Ике дистә ел буена чарлаган икән инде ул шигырьләрне. Мөгаен, хәлсезрәк, төссезрәкләрен ташлагандыр (типкән саен, җирдән алтын чыкмый бит)*. Н.Каштанов. **Типсә тимер өзәрлек (өзәрдәй)** Бик таза, көчле һәм гайрәтле. *Аларны капка төбендә тарантаска җигелгән яхшы ат, типсә тимер өзәрдәй ике егет көтеп тора иде*. Г.Бәширов. *Бөтен килеш-килбәтеннән типсә тимер өзәрлек икәнлеге әллә каян сизелеп тора*. М.Хәсәнов

**Тибә башлау** Тибәргә тотыну. *Әрләннең, акча күргәч, күзләре ут янды, чигә тамырлары тибә башлады*. М.Галәү. *Ярату язмышка әверелсә, дуслыкны читкә тибә башлый шул*... Г.Гыйльманов

**Тибә тору** Тибүен дәвам итү. *Бер минут узмагандыр, йодрык белән суга, аяк белән тибә торгач, бизәкле ишек чатыр-чотыр килә башлады*. К.Миңлебаев

**Тибә язу** Чак кына типми калу. *Ә менә монысы типкәләргә ярата, сакчы Шәһәйнең корсагына тибә язды*. А.Гадел

**Тибеп алу** Бер тапкыр тибү; тиз арада тибү. *Итек кунычын ике ягыннан эләктереп, җан ачуы белән тагын бер тапкыр сайгакка тибеп алды да турайды*. М.Хәсәнов. *Өйдә чит кеше булмаса, тәрбия йөзеннән ул аның ләшперәйгән чалбар төбенә берне тибеп алырга да күп сорамас иде, әлбәттә*. Ф.Садриев

**Тибеп җибәрү** Кинәт тибү. *Карчык аңа әйләнеп тибеп җибәрде һәм --- Мәңгүк ханга текәлде*. М.Хәбибуллин. *Тикшерүче очынып килә дә аңа күн итеге белән тибеп җибәрә*. Р.Кәрами

**Тибеп карау** Сынау өчен тибү. *Ул --- киселгән агачның төбен бер әйләнеп чыга, аңа балта белән бәреп карый. Аягы белән төпкә тибеп карый*. М.Мәһдиев. *Әллә ничә малай тибеп карадылар, әмма капкага кертә алмадылар*. Р.Фәизов

**Тибеп куюу** *к.* **тибеп алу**. *Немецларның берсе Габдрахманга тибеп куйды*. З.Зәйнуллин. *Явызлыкның үзе булып килеп кергән Хәмис Айдарга тагын бер тибеп куйды да --- чыгып китте*. Г.Гыйльманов

**Тибеп ташлау** Бик тиз арада көч белән, очыртырлык, төшәрлек итеп тибү. *Нургали юрганын тибеп ташлады да урыныннан сикереп торды*. Ә.Еники. *Киткәненең беренче көнендә үк әрсез чебешләр, әллә кайлардан койма тишекләре табып, бакчага кереп, суган түтәлен тибеп ташларга өлгерделәр ---*. Ф.Яхин

**Тибеп тору** Әле, хәзер тибү; бертуктаусыз яки әледән-әле тибү. *Мин бит бу сүзне аңымны югалткан минутларда да исемнән чыгармадым, гүя чигәмдәге кан тамыры шикелле, ул өзлексез тибеп торды*. Ә.Еники. *Өйнең калай түбәсе астында еллар буе торып тәмам җитлеккән, камыт бөятедәй итеп бәйләнгән казылыкның майлары тибеп торыр иде*. Н.Хәсәнов

**ТИБҮ** II *и.* Елганың кискен борылган һәм су басымыннан ярлары ишелеп, бик киңәеп киткән урыны, тоба. *Кыелып төшкән текә яр бетеп, су читеннән үк чирәмлек башланды, елга тибүе дә җәелеп, киңәеп китте*. Х.Сарьян

**ТИГӘНӘ** *и.* 1) Агачтан чокып ясалган озынча улак, тар ялгаш, тагарак. *Анда умывальник та бар. Ул бик зур, үзе тигәнә төсле, үзе фарфордан эшләнгән*. А.Алиш. *Үгез, юан муенындагы калын чылбырларын шалтыр-шолтыр китереп, авыр, итләч гәүдәсен тибрәтеп, әле ул тигәнә тирәсендә генә йөренеп тора*. Ф.Җамалетдинова

2) *сир. к.* **җилпуч** (*1 мәгъ*). *Арт келәткә чыктым ничек, Бер тигәнә он өчен? Унбиш яшькә җиттем ничек, Кырык биш яшьлек тол өчен?* Җыр

**ТИГӘНӘК** *и.* **1.** 1) Оешмачәчкәләр семьялыгыннан киң итләч яфраклы, ябышкак чәнечкеле шарчыксыман орлык тартмасы булган икееллык үсемлек; әрекмән; *русчасы:* **репейник**. *Киртә буендагы тигәнәкләр арасында бер-ике баланың саргылт башы күренеп алды ---*. М.Мәһдиев. *Таудан төшүгә, --- ат кузгалаклары, озын-*

*озын тигәнәкләр, алабуталар үсә, таллыклар бар.* Ә.Сафиуллин

2) Шул үсемлекнең шарчык рәвешендәге ябышкак чәнечкеле җимеше, сырышучан орлык тартмасы. *Аның тиргә манчылган ак күлмәге тәненә сыланган, яңа чалбары таушалып, балакларына ат төкләре, тигәнәкләр ябышкан, ботинкалары соры тузанга манчылган.* Г.Әпсәләмов. *Чаңгылары әрем сабакларын керт-керт сындырды, таудан очып кына төшсә дә, йон бияләйләренә, яңа бишмәтенә әрсез тигәнәкләр ябышырга өлгерде.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ. күч.* Күңелгә тия, газаплый, йөдәтә, борчып тора торган. *Болай да җәрәхәтле, телгәләнгән йөрәккә тоз сибәләр. Һаман бер тигәнәк сорау.* И.Салахов

◊ **Тигәнәк белән сырганак шикелле (кебек)** Бер-береннән аерыла алмый, шул ук вакытта гел үзара әрепләшергә, тиргәшергә генә торган ике кеше турында. *Очрашсак, юньле сүзебез юк, тигәнәк белән сырганак шикелле ябышырга гына торабыз.* А.Гыйләҗев. **Тигәнәк кебек сарылу** Бәйләнү, берәр кешегә тагылу, яныннан китмәү. *Ул чакларда Әлифә --- ата күңеленең җылысын яхшы тоя иде. Шуңа күрә, Кәрим абзый эшеннән кайтып керүгә, өстен алыштырырга да форсат бирмичә, тигәнәктәй барып сарыла.* Г.Сабитов. **Тигәнәк кебек ябышу** *к.* **тигәнәк кебек сарылу**. *Гәүһәр тагы тигәнәк кебек килеп ябышыр: нигә әйткәнчә эшләмәдең дип, күзеңне ачырмас.* Г.Ибраһимов. *Синең белән очраша башлагач, Айтуганны бөтенләй онытканмын икән, ул миңа, кая барсам да, тигәнәктәй ябышырга гына тора.* Ф.Яруллин

**ТИГӘНӘКЛЕК** *и.* Тигәнәкләр күпләп үскән урын. *Вәкил ---: «Әнә, Габбасов хәтта тигәнәкне дә ничек оста файдалана белә, казлар симертә тигәнәклектә, үрнәк алыгыз», – ди икән.* Р.Төхфәтуллин. *Без тигәнәклеккә килеп җитеп, ак курай йолкырга керештек.* Н.Сәфәров

**ТИГЕЗ** *с.* **1.** 1) Шома һәм яссы; кытыршы урыннары, чокыр-чакырлары булмаган. *Биредә тигез дала тәбәнәк калкулыклар, инешсез коры үзән-ярлар белән телгәләнә.* Х.Камалов. *Аэропорт болын кебек тигез мәйданнан һәм авыл мунчасыдай кечкенә генә йорттан гыйбарәт.* Р.Вәлиев

2) Бердәй, бер-берсенә тиң, тиңдәш; үзара бер үлчәмдәге, бер зурлыктагы; бер-берсен төгәл кабатлаган, бертөсле. *--- яңа үсә башлаган чәчәкләр дә көләч йөзләре белән аның күзләрен иркәлиләр, кыскасы, бөтен табигать моны башка адәмнәр белән бер дәрәҗәдә күрә, бирә алганын тигез өлештә моңар да бирә иде.* Ф.Әмирхан. *«Бәгырь авазы»н үз көем белән укыйм һәм --- тигез үлчәмле ритмнарында дала иңләп килгән атларның тояк тавышларын --- ишетәм.* Р.Харрасова

3) Бер үк төрле, бер үк юанлыкта, калынлыкта, куелыкта, төстә булган (җеп, бау, сызык һ.б. тур.). *Аның [Зөһрәнең] эрләгән җебе дә тигез, матур.* А.Әхмәт

4) Вакыт үлчәмендә үзгәрешсез, бер көйгә, бер ритмга дәвам итә торган; салмак. *Фаягөл, баланың йөзенә якын ук килеп, аның тигез сулышына бертын ләззәтләнеп торды, өстендәге җәймәсен рәтләгәндәй итте.* А.Әхмәтгалиева. *Тәпиләрен тимер рельсларга кыйный-кыйный, авыр сыннарын тигез хәрәкәткә буйсындырып, поездлар бер-бер артлы үтеп кенә тора.* Ф.Җамалетдинова

5) Чокыр-чакырсыз, сикәлтәсез, такыр. *Киң, тигез юлдан җиңел генә тәгәрәгән автомобиль соңгы җылы яңгырлар белән күтәрелеп киткән басуга килеп чыкты.* А.Шамов

6) Туры сызык буенча барган, туры сызык хасил иткән. *--- лагерьның зур тимер капкасыннан, тигез сафларга тезелеп, ике ротага якын солдат-сержант килеп керде.* З.Зәйнуллин

7) *күч.* Тулы (ире дә, хатыны да булган гаилә тормышы тур.). *Тыныч, тигез тормышлы ике гаилә башлыклары да балалары дуслыгына сөенеп бетә алмады.* А.Хәйртдинова. *Сезгә --- какшамас саулык, иман байлыгы, куанычлардан гына торган тигез тормыш, хәерле гомерләр телим.* Т.Нәҗмиев // Гомумән тату, дустанә. *Бары тик үз халкының мул, тигез тормышына, байлыгына таянган ил генә алга бара, чәчәк ата ала...* М.Хәсәнов

8) *күч.* Үзара тиң, бер үк дәрәҗәдәге. *Миңа калса, Русиядә бөтен милләтләргә дә тигез хокук һәм мөмкинлекләр бирелгән.* И.Хуҗин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Туры итеп. *Чәчләре коңгырт кара, калын кашлары тигез сызылган.* Р.Кәрами

2) Шома итеп, шома булып; тигезсезлек, кытыршылык калдырмыйча. *Башта тырнакка нигез лак буярга кирәк. Ул төрле тигезсез урыннарны каплый һәм декоратив лакның тигез буялуына ярдәм итә.* Матур буласың килсә

3) Нәкъ бертөсле итеп, бердәй. *Тигез күрә бөтен җанны театр.* Г.Тукай. *Ренат Харисның татар халкына --- багышлап язылган бик күп шигырьләре бар. Аларда – татар өчен горурлык хисләре дә, татарны олы итеп, башка олы халыклар белән тигез итеп күрәсе килү теләге дә!* Р.Миңнуллин

4) Тиң булып, бердәй. *Бер өй эчендә нәкъ илле егет Тигез үскәннәр үлчәгән кебек.* З.Туфайлова

5) Бер үлчәмдә. *Тотылган балыкларны ике ир үз капчыкларына тигез бүлеп салдылар.* Г.Гыйльманов

6) Бердән, берьюлы. *Бакчага чәчтем чәчкәләр, Түгәрәк түтәл ясап. Бар да тигез шытып чыкты, Саный китсәң – бихисап.* Ф.Тарханова

7) Бер үк ритмда, бер көйгә, үзгәрешсез; салмак. *Ул, --- гәүдәсен авылчарак тотып, әмма үзенә бертөрле килешле йөреш белән, матур аякларын тигез басып, ныклы адымнар белән килә иде.* Р.Кәрами. *--- болытлар --- җил чыгармыйча гына теплоход өстеннән үтеп китә. Көнчыгыш иллюминаторлардан кергән кояш баганасы, тигез янмаган лампа кебек, янып-сүрелеп, янып-сүрелеп ала.* К.Кәримов

8) Синхрон рәвештә; бер дәрәҗәдә. *Аның белән бергә тигез атлап, штыклы автоматларын нык тотып, яшь моряклар колоннасы барды.* Н.Фәттах. *Башта бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек.* Ә.Хөсни

9) *күч.* Тыныч, шау-шусыз гына. *Тигез генә тәгәрәгән җиреннән бервакыт*

*Камәр карчыкның тормышы тагын сикәлтәле юлга барып керде.* М.Мәһдиев

**3.** *хәб. функ.* 1) Билгеле бер нәрсә белән бер яссылыкта, бер тәңгәлдә, бер югарылыкта, бер биеклектә; төп-төгәл; тиң. *Шунысы хәтердә: иртән Муса янына дусты килгәли иде. Аның белән бер яшьтәгеләр булыр. Буйлары да тигез иде.* Казан утлары. *Ике команданың көчләре тигез иде.* Сабантуй

2) Нәрсә беләндер бер үк кыйммәткә ия, шуңа бәрабәр. *Шактый озак әзерләнгән һәм шактый вакыт үз сәгате сукканны көтеп яткан программа ул. Бәһасе аның 279 (!) миллиард сумга тигез.* Р.Фәйзуллин. *Август ахырына булган мәгълүматларга караганда, авыручылар саны 289 га тигез.* Шәһри Казан

◊ **Тигез җирне түмгәк итү** Үлү, кабергә керү. **Тигез урында түмгәк** «Исәпкә бар, санга юк» мәгънәсендә кулланыла. *Син яшәмә җирдә файдасыз бер Түмгәк булып тигез урында.* М.Җәлил

**ТИГЕЗЛӘГЕЧ** *и.* 1) *тех.* Берәр предметны төгәл горизонталь яки төгәл вертикаль торышка кую өчен кулланыла торган җайланма. *Бала чакның гаҗәп әйберләреннән берсе булып, балта остасының бүрәнәгә куеп карый торган тигезләгече истә калган.* Ш.Галиев. *Аларның кулларында тигезләгеч, шпатель, пумала кебек инструментлар уйнаклап торыр, шул арада үзара гәп тә куертырлар* ---. Р.Кәрами

2) Кирпечтән йорт һ.б.ш. биналар салганда кулланыла торган линейка, правило

**ТИГЕЗЛӘМӘ** *и. мат.* Билгесез зурлыкларны табу өчен төзелгән математик формула. *Иҗат – илһам эше, ә илһам мең билгесезле, югары дәрәҗәле математик тигезләмә белән бер.* А.Тимергалин. *Иррациональ тигезләмәләрне чишү буенча үткәрелгән дәрескә анализ бөтенләй барып чыкмады.* Н.Көбәш

**ТИГЕЗЛӘНЕШ** *и.* 1) *физ.* Хәрәкәтсез торган яки тигез хәрәкәт иткән җисемнең яисә системаның аңа тәэсир иткән төрле көчләр яки вакыт нәтиҗәсендә бер-берсен юкка чыгаруы белән характерланган күренеш; *русчасы*: **равновесие**. *Әгәр авырлык көче юнәлеше --- таяныч ноктасы аркылы үтсә, линейка (җисем) тигезләнеш хәлендә булыр.* Физика. *Механик хәрәкәтнең законнарын һәм матди җисемнәрнең тигезләнеш (тикторыш) шартларын кешелек дөньясы бары тик күп кабатланучы күренешләр, саф экспериментлар нигезендә генә төшенә, аңлый алган.* Фән һәм тел. *Тотрыклы тигезләнеш. Тотрыксыз тигезләнеш. Тигезләнеш законы*

2) *физ.* Тотрыклылык; җисем яки системаның хәрәкәтсез торганда тотрыклылыгын саклавы; *русчасы*: **устойчивость**

3) Берәр нәрсәне тәшкил иткән өлешләрнең үзара тигез булуы; баланс. *Кеше – чынбарлыктагы матди һәм мәгънәви башлангычлар берлеге, аларның үзара көрәше нәтиҗәсе. Юнан мәдәнияте – менә шул көрәшнең кеше хәяты аша тышка бәреп чыгуы, матдирухи тигезләнешнең бозылуы.* Т.Әйди

4) Катлаулы, каршылыклы процессларның яки капма-каршы юнәлгән көчләрнең, хәрәкәтләрнең үзара зур үзгәрешләр ясау тәэсирен йомшарту, тоткарлау, юкка чыгару күренеше. *Чимал һәм эш көче болай да җитешмәүгә карамастан, үзәк ведомстволар Эстониядә яңа ГРЭСлар, ашлама заводлары корырга ниятли. Моның исә табигатьне, шул исәптән эстон халкын саклауга, киң мәгънәдә алсак, экологик, социаль, милли тигезләнешенең бозылуына китерәчәге ачыклана.* Т.Әйди. *Гармония ул – хәрәкәт чыганагы да: әлеге көчләр тигезләнеше (берсен икенчесе юк итә алмавы) аркасында хәрәкәт һичкайчан да туктамый, нейтральлектән яңа триада барлыкка килә.* Р.Сафин

5) *күч.* Күңел тынычлыгы, рухи яктан борчылмый, дулкынланмый яшәү халәте; гармония. *Ул чакта бу җыр һәм аңа сүзләр уйлау аның кәефен бер тигезләнештә, бер яссылыкта тотып торган иде.* Ә.Гаффар

**ТИГЕЗЛӘНЕШЛЕ** *с.* Тигезләнештә торган; тигезләнешне саклаган. *Тигезләнешле процесслар өчен термодинамиканың икенче законын түбәндәге тигезләмә рәвешендә язып була ---.* Фән һәм тел. *Тигезләнешле хәрәкәт*

**ТИГЕЗЛӘНЕШСЕЗ** *с.* Тигезләнеше сакланмый торган. *Статистик физиканы тигезләнешле һәм тигезләнешсез (физик кинетика) бүлекләргә бүләләр.* Физика

**ТИГЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тигезләү**. *Ә менә --- моннан 30–40 еллар элгәре бульдозер белән эттереп тигезләнгән курган-корганнарның эзләрен кем табып бирер икән?* Б.Рәхимова. --- *Мөштәри урамындагы йорт сүтелеп беткән, ә аның урыны җир белән тигезләнгән булып чыкты.* Г.Гыйльманов

2) Яссы, тигез булып китү, үзлегеннән тигез хәлгә килү. *Ломның тупас башы белән бәрә торгач, шанның [чанның] яньчелгән җире тәмам тигезләнде.* Ш.Камал. *Агач тамырларын бульдозерлар тартып чыгарган чокырлар, түмгәкләр еллар үтү белән тигезләнделәр* ---. Р.Хәбибуллина

3) Шомару; такыраю. *Бөялгән бозлар да китеп бардылар. Су өсте тигезләнеп, чистарып калды.* Н.Хәсәнов. *Фәлән-фәлән кремнарны сөртсәң, атнаун көн эчендә үк җыерчыклар тигезләнеп, бит шомара, имеш.* Җ.Харисов

4) Хәрәкәт, агым, процесс, темп үзгәрми башлау, тигез булып китү, тигезгә әверелү. *Һәм менә тагын кан басымы күтәрелде. Күзләре күрми. Басым тигезләнү белән, иншалла, ачылачак алар.* А.Хәлим. *Гали, кабынган сулышын бераз гына булса да җиңеләйтергә теләп, җиргә чүгәләде һәм шактый вакыт шул хәлендә сулыш алуы тигезләнгәнен, йөрәге тынычланганын көтте.* Г.Галиев

5) Туры хәлгә килү; бер туры сызыкка басу. *«Смирно»! – дигән әкрен команда ишетелде. Сафлар тигезләнеп, тынып калдылар.* Г.Әпсәләмов

6) Бер яссылыкта, бер биеклектә, бер ераклыкта калу, бердәй урын алу, тәңгәлләшү. *Аннан соң, атларны иркенгә куеп, ике җайдак тигезләнде ---.* Р.Батулла

7) Кемгә, нәрсәгә, кем яки нәрсә белән дә булса тиңләшү, бер дәрәҗәгә килү. *Хатын-кызларда көмешсыман, корычсыман булып агара башлаган чәчләр модага керде. Мөгаен, өлкәннәр хәйләседер. Яшьләр белән тигезләнү өчен.* Ш.Галиев. *Шуннан соң миннән*

*ямьләнү әйберләре ясаткан апайларның дәрәҗәләре тигезләнә дә китә. Барысы да бер кавем – ямьле кавем була аннары, һәркайсының күңел кояшы нурлырак балкый аннары.* М.Хуҗин

8) Бер-берсенең тәэсирен йомшарту, йоту, юкка чыгару (капма-каршы юнәлгән көчләр тур.). *Кемгә ничектер, әмма миңа калса, яшәү белән үлем мәсьәләсе без кичергән заман белән бик нык бәйләнгән булып чыкты. --- Шуның аркасында яшисе килү белән дөньядан бизү гүя үзара тигезләнделәр.* Ә.Еники. *Җисем тикторыш хәлендә булганда, --- аңа тәэсир итүче көчләр үзара тигезләнеп торалар.* Физика

9) *күч.* Яхшыру, җайлану, җитеш хәлгә килү. *Дөньябыз түгәрәкләнде, тормышыбыз тигезләнде, ниһаять, татарлыгыбыздан арындык дип, борын чөйдек.* И.Диндаров

**Тигезләнә бару** Акрынлап, торган саен тигезләнү. *Инде тормышлар яхшыра һәм бәхетләр тигезләнә барган саен, ул орлыклар тулысынча шытып, барлык кешеләрнең дә үзара мөнәсәбәтләре менә шулай якты, җылы булып китмәсмени?* Ә.Еники. *Әнисе киткәч сабый җанында туган упкын әкрен-әкрен тигезләнә бара иде төсле.* Ф.Яруллин

**Тигезләнә башлау** Тигезләнергә тотыну. *Тоткыннар теләр-теләмәс кенә тигезләнә башладылар.* Г.Әпсәләмов

**Тигезләнә төшү** Бераз тигезләнү; тагын да тигезләнү. *Шуннан соң Зиннуровның сулышы тигезләнә төште, күзләрен ачты.* Г.Әпсәләмов. *Карчыкның тавышы тигезләнә төште.* М.Хәсәнов

**Тигезләнә язу** Тигезләнүгә бик якын калу. *Тагын күпмедер вакыттан соң гына, аларган күзләре үз орбиталарына кайткач, сулышлары тигезләнә язгач кына, алар шаркылдап көләргә керештеләр.* Ә.Баян. *Уртадагы хатыннар бер тирәдәрәк баралар. Хәер, берсе нык алга киткән, теге көндәшләр белән тигезләнә язган бит.* М.Маликова

**Тигезләнеп бетү** Тәмам, тулысынча тигезләнү. *Сүз дә юк, кешеләр хәзер җиңелрәк тә, яхшырак та торалар, әмма шуның белән бергә аларның килерләре тигезләнеп беткәне юк бит әле.* Ә.Еники. *Үле тынлык дигән нәрсә шушы инде: монда кошлар оя типми; сандугач сайрамый --- түмгәкләре җир белән тигезләнеп бетkән ---.* А.Тимергалин

**Тигезләнеп җитү** *к.* **тигезләнеп бетү**. *Айтуган карт, үлчәү теле тигезләнеп җитүгә: – Җитмеш ике ---, – дип кычкырып куя.* Г.Бәширов. *Әле генә кеше күмелерлек булган тирән чокыр һаман саега бара һәм менә тагын бер ун бадьядан соң өске кырый белән тәмам тигезләнеп җитте ---.* Ш.Маннур

**Тигезләнеп тору** Һәрвакыт, даими рәвештә тигезләнү. *Яшәешең эчке халәтеңә тигезләнеп тора.* Ш.Галиев. *Гомереңнең уңай барышында Тигезләнеп тора тоташ юл.* Ф.Яхин

**ТИГЕЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тигез, шома итү, тигезлеген булдыру. *Түгәрәкләнгән тоякны вак тешле рашпиль белән шомартып тигезләгәннән соң, даганы тоякка кадаклый башлады.* З.Зәйнуллин. *Печән кибәнен салып, очлап бетергәч, аны як-яктан тырма белән тарап матурлыйсың, тигезлисең.* М.Мәһдиев

2) Чокыр-чакырлы, тигезсез урынны тигез җиргә әверелдерү, такырлау. *Ул чүлмәк тирәсендәге җир өстен тигезләгәндәй итте дә көрәген кире урынына илтеп куйды.* Н.Фәттах. *Торабара ул чокырны күмделәр, тигезләделәр.* Ф.Яруллин

3) Турылау, бер туры сызык рәвешенә китерү, бер юнәлеш буенча урнаштыру, тезү, төзү, ясау. *Вахтёрлар --- җирдә утырганнарны аяклары белән тибеп, басканнарны этеп-төртеп сафларны тигезләргә, колоннаны «тантаналы парадка» – түрәне каршылар өчен әзерләргә тырышалар.* И.Салахов. *Кечкенә тимер калак белән измә җәясең дә өстенә яңа кирпеч куясың. Аннары, калак сабы белән суккалап, кирпечне тигезлисең.* Н.Әхмәдиев

4) Нәрсәне дә булса бердәй юанлыкта, калынлыкта итү. *Җепне тигезләп кату*

5) Нәрсәләрне дә булса бер-берсенә туры китерү, бер сызык буенча яки бер яссылыкка кую. *Инде лампа филтәләрен кайчы белән тигезләп кистеләр, инде эссе лампа куыкларын өрә-өрә кабат чистарттылар ---.* М.Мәһдиев. *Шул гайкаларның әле берсен, әле икенчесен борып, сынган сөякне тигезлиләр икән.* Ф.Яруллин // Бер тәңгәлгә китерү; бер сызыкка кую. *Биредә юртакларны бер сызыкка тигезләп тезеп маташмадылар.* В.Имамов. *Үлчәүне тигезләгән кыяфәт чыгарып, товар куелган якны бармак башы белән генә аска да басканнар яисә кәгазь кыстырып калдырганнар ---.* Татарстан яшьләре

6) Бер үлчәмдә, бер күләмдә итү; тигезләп бүлү, бертигез, тиң, бердәй һәм бер-берсенә туры килерлек итү. *– Печән саткан акчаны тигезләп бүлерсең, монда синнән дә белемле кеше юк, – диделәр.* Р.Газизов. *Премьер-министр постына билгеләнгәч, Путин, инде киләсе елдан ук яшәү минимумы белән минималь хезмәт хакы күләмен тигезләргә кирәк, дигән мәсьәләне күтәрде.* Татарстан яшьләре

7) Дәвамлы процессларны үзгәрми торган темпка, ритмга салу. *Ул, сулышын тигезләргә тырышып, беравык торды да, идәнгә чап-чоп басып, үз бүлмәсенә борылды.* А.Гыйләҗев. *Әгәр сәламәтлектә җитди проблема табылмаса, йөрәк тибешен тигезләү өчен махсус күнекмәләрдән башларга, шулай ук көн саен иртән һәм кич өчәр чакрым җәяү йөрергә тәкъдим ителә.* Сәламәт булыйк!

8) *күч.* Берәр берәмлекне, санны үрнәк итеп алу, шуның белән чагыштыру, шуңа яраклаштыру. *Менә шушы курантларга карап, Сәгатьләрне тигезлибез без.* Ә.Ерикәй

9) *күч.* Тәңгәлләү, тиңләү. *Шәйдулла зур белеме булмаса да белә: бер атның көчен таза җиде ир кеше көченә тигезлиләр.* М.Мәһдиев

10) *күч.* Һәрьяклап яхшырту, матур итү. *Бар кешене тиңләдем мин игезләргә – Омтылдым гел бу дөньяны тигезләргә ---.* Г.Мөхәммәтшин. *XIX йөзнең беренче яртысында башланган гомуми уяну хәрәкәте җирлегендә тормышны тигезләү --- кабат игътибар үзәгенә куела.* С.Шәйдуллин

**Тигезләп алу** Тиз генә тигезләү. *Караватына кул тидереп, тигезләп алды.* Р.Кәрами

**Тигезләп бару** Рәттән тигезләү. *Ул элекке ялгышлары өчен хәзергесе белән*

*түли генә ала. Үз балансын кеше шулай гына тигезләп бара.* Х.Камалов. *Инде юллар да сала башлаганнар: өсләренә кыска тун кигән таза-таза егетләр туң җирне жылытып тигезләп баралар ---.* М.Зарипов

**Тигезләп бетерү** Барысын да тигезләү. *Меңләгән, ун меңләгән тояклар таптаган, шулай да таптап, тигезләп бетерә алмаган биек үләннәр арасында берөзлексез чикерткәләр чәкелдәде, кошлар сайрады.* Н.Фәттах

**Тигезләп җибәрү** Бераз, беркадәр тигезләү. *– Бабай, сакал-мыегыңны тигезләп җибәрсәк, ничек булыр икән? – диде Нургаяз.* Ф.Яруллин. *Тирән эчле табага ит чумарларын тезеп, алар өстенә әле генә әзерләгән кабак соусын салабыз һәм кашык белән бераз тигезләп җибәрәбез.* Сөембикә

**Тигезләп карау** Тигезләргә тырышу, тигезләргә омтылу. *Палач аның муенына бау төшереп тигезләп карый...* Р.Төхфәтуллин

**Тигезләп килү** Күптәннән тигезләү. *Бар дөньяны гел тигезләп килде, Аермыйча дуска-дошманга.* Х.Әюп

**Тигезләп кую** Тигезләнгән хәлгә китерү; алдан тигезләү. *--- чүлмәкнең туфрак белән күмелми калуын исенә төшереп, ул тиз генә алмагач янына килде, көрәк белән чүлмәкне күмде дә тирә-яктагы балчыкны тигезләп куйды.* Н.Фәттах. *Зур сай тәлинкәгә пешкән бәрәңгене зур тишекле угычта уып сал һәм кашык белән тигезләп куй.* Матур буласың килсә

**Тигезләп ташлау** Бик тиз арада тигезләү; бөтенләйгә тигезләү. *Сугыш бик күп нәрсәне, бик күп төшенчәләрне, бик күп кешеләрне тигезләп ташлады.* З.Хәким

**Тигезләп тору** Һәрвакыт, гел тигезләү. *Гыйбаш абзый, халыкка йөрергә якын да, җайлы да булсын дип, тау кыройларын казып, яңа юллар сала, кырынярын юлларны әледән-әле тигезләп тора ---.* Г.Бәширов. *Бездә газоннарны да машина белән кыркып, тигезләп торалар.* Ф.Баттал

**Тигезләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тигезләү. *Яңа китапларымны актарып, ялгыш бөкләнеп калган битләрен тырнак белән ышкып тигезләп чыккач, --- аларны киштәдәге дәрәҗәле урынга, үз ишләре янына куйдым.* А.Тимергалин. *Сәвия койма башларын карап кайтканчы, Рәшит абыең бульдозеры белән урамны тигезләп чыкты.* Н.Кәримова

**Тигезли бару** Рәттән тигезләү

**Тигезли башлау** Тигезләргә тотыну. *Ләкин немец танкысы, үлем ачысы белән дошманына ташлана торган яралы ерткыч кебек, коточкыч сикереш ясады, окоп өстендә ажгырынып әйләнеп, аны җир белән тигезли башлады.* Г.Әпсәләмов. *Менә кеше шулай икегә бүленде: гәзиттә – бер төрле, тормышта – икенче, ике арадагы аерманы аракы белән тигезли башлады кеше.* М.Мәһдиев

**Тигезли тору** Тигезләүне даими дәвам итү. *Тигезли торгач, һәммәсен дә тигезләп бетермәсәгез ярый да бит.* Р.Мөхәммәдиев

**Тигезли төшү** Тагын да бераз тигезләү; бераз гына тигезләү. *Күз яшьләрен сөртә-сөртә, сулышын тигезли төшкәч кенә, өзек-өзек сүзләре чыга башлады ---.* Ф.Баттал

**ТИГЕЗЛӘҮЧЕЛЕК** *и.* 1) Кешеләр хезмәтенә, аның күләменә һәм сыйфатына карамыйча, бердәй тигез түләү системасы. *Алар арасында авыл мәктәпләренең педагогик кадрлар белән начар тәэмин ителүе, педагогик хезмәткә түләүдә тигезләүчелек --- һәм башкалар – Г.Габдуллин боларның барысын да аңа гына хас булган энергия белән хәл итәргә алына.* Шәһри Казан

2) Кайсы да булса реаль социаль-сәяси шартлар белән расланмаган тигезлек, тиңлек. *Региональ хуҗалык исәбенә күчүнең киң яклау табуы очраклы хәл түгел, чөнки ул өлкәләр, республикалар, районнар һәм шәһәрләр арасындагы урынсыз тигезләүчелекне бетерергә, гаделсезлеккә чик куярга --- мөмкинлек бирә.* Казан утлары

**ТИГЕЗЛӘШҮ** *ф.* 1) Кемнең яки нәрсәнең турысына барып җитү, куып җитү. *Ул инде Сәүбән белән тигезләште, аннары, керфек тә какмыйча, авызын турсайткан килеш, килгән җайга узып та китте.* Г.Гыйльманов

2) Үзара тигезләнү. *Беләсеңме, идән асты чокыры, еллар дәвамында күмелеп, җир белән тигезләшсә дә, казылмаган каты балчыктан барыбер аерыла икән.* А.Гыймадиев. *Шәрык календаре буенча Яңа ел – көн белән төн тигезләшеп, яңа көн туу бәйрәме иде бу.* А.Нәҗми

3) *күч.* Кем белән дә булса эштә, ярышта һ.б.ш.да бер дәрәҗәгә житү, аның белән бер сафка басу. *Камил белән укуда гына булса да тигезләшер өчен, Канифә диңгез кичәргә әзер иде.* Н.Көбәш

4) *күч.* Кемгәдер тиңләшү, аның белән бер дәрәҗәгә күтәрелү яки төшү. *--- көннән-көн гамьсезләнә барган ир тормыш баткагына муеннан кереп чумачак! Биргән вәгъдәләрен, эчкән антларын онытачак, сары йорт бәндәләре белән тигезләшеп, ярты хайванга әйләнәчәк.* А.Гыйләҗев. *Я, әйтегез! Кайсы як Моңсары Тукай белән тигезләшә алыр?!* Ф.Гыйззәтуллина

**Тигезләшә бару** Акрынлап, торган саен ныграк тигезләшү. *Димәк, гаилә үлчәве тигезләшә бара.* Ватаным Татарстан. *Миңа калса, ир белән хатын статусы тигезләшә бара.* Туганайлар

**Тигезләшә башлау** Тигезләшүгә якын булу. *Каршыга килүче, алар белән тигезләшә башлагач, көч-хәл белән атын туктатты.* Ф.Сафин. *Тик һаман саен күбәйгән кулланучылар саны нәтиҗәсендә чыгымнар керемнәр белән тигезләшә башлаган.* Ватаным Татарстан

**Тигезләшә язу** Чак кына тигезләшми калу. *Тәвәккәллек тә бик тиз төкәнде, милли аң да нульгә тигезләшә язды.* Р.Юныс. *Алла Пугачёва белән тигезләшә яздык ул көнне популярлыкта.* Ватаным Татарстан

**Тигезләшеп бетү** Тәмам, бөтенләй тигезләшү. *--- күңелендәге моңысагышы үзе сөйли торган шигырьләрнеке, табигать балаларыныкы белән тигезләшеп беткән.* Р.Шәрәфиев

**Тигезләшеп җитү** *к.* **тигезләнеп бетү**. *Әле «Волга» белән тигезләшеп җиткәнче үк, алар котырып ут ачтылар, ә янәшәдән узганда, машинаны иләккә әйләндергәннәр иде инде.* Р.Мирхәйдәров

**Тигезләшеп калу** Тигезләшкән хәлгә килү. *Ул үзенең капкасы турына җитүгә туктап калды: кичкырын Ык суы арта башлап, яр белән тигезләшеп калган иде.* Ф.Садриев. *Мотор шундук сүнде, кызны уч төбендәгедәй югары күтәреп барган көймә борыны су өсте белән тигезләшеп калды.* Р.Мөхәммәдиев

**Тигезләшеп карау** Тигезләшергә тырышу. *Ул – председатель – аягында нык басып тора. Аның белән тигезләшеп кара!* Н.Хәсәнов

**Тигезләшеп килү** Акрынлап тигезләшү, тигезләшү алдында тору. *Аның да тол калып яшәгән еллары ирле гомер кичкән чагы белән инде тигезләшеп килә.* Г.Сафиуллина. *«Татарстандагы бензин бәяләре хәзерге вакытта дөнья илләрендәге уртача бензин бәяләре белән тигезләшеп килә ---», – дип белдерә һөнәри берлекләр хезмәткәрләре.* Р.Шакир

**Тигезләшеп тору** Тигезләшкән хәлдә булу; гел тигезләшү. *Тигезләшеп торыр чакмыни, бернигә карамый алга ыргылганнар гына ота бүген.* Яңарыш

**ТИГЕЗЛЕК** *и.* 1) Тигез булу сыйфаты; тигез булу хәле. *Өй каршындагы рәшәткә такталарының тигезлеге тартылган кыл кебек.* Н.Хәсәнов. *Урман чытырманлыгы ничек аптырашта калдырган булса, асфальт юл тигезлеге дә зур табышмак иде минем өчен!* М.Вәлиев

2) Тигез җир; тигез урын. *Яшел тигезлекләр – бодай, арпа басулары, кая карама, анда лимон, әфлисун, агачлар арасында сары алтындай ялтырап, күзеңнең явын ала.* М.Мәһдиев. *Калкулык өстенә менеп җиткәч, калкулык итәге буйлап бормаланып сузылган инешнең теге ягына, тигезлеккә урнашкан авыл күренде.* Р.Гариф

3) Бер-берсенә үлчәм, зурлык, күләм ягыннан тиң булу. *Мисаллардан күренгәнчә, фразеологизмнар төзелешендә шундый бер принцип сакланган: аларның компонентлары авазлар охшашлыгын, иҗек саны тигезлеген, сүзләрнең озынлыгын-кыскалыгын һ.б. исәпкә алып сайлап алынган.* Р.Йосыпов

4) Турылык, төзлек. *Әхлетдин бабай пычкыны, кайрап бетереп, югары күтәрде, бер күзен кысып, тешләренең тигезлеген карый башлады.* Г.Әпсәләмов

5) Таяну нокталары аз булган җисемнәр тотрыклылыгы. --- *катңак боздан мәет күтәреп барышлый, зират янындагы инешне чыкканда, егетләрнең берсе таеп китте дә, калганнары да сөрлегеп, тигезлекне югалтып, мәетне бозлы балчыкка төшерделәр ---.* М.Мәһдиев. *Ул, җир катысын тоярга теләгәндәй, гәүдәсенең бар авырлыгын сул аягына күчерде һәм, тигезлек саклый алмыйча, янтаеп китте.* Р.Вәлиев

6) Тормыш, яшәү ягыннан үзара тиңлек, тиң булу хәле. *Дөньяның бөтен яме, тәме – тигезлектә.* М.Мәһдиев. *Башка заводныкыларга караганда пенсиягә ун елга алданрак чыксалар да, тигезлек белән картаерга язмаган: Мөнирә апаның ире Ленин яшенә җиткәч җан тәслим кылды.* К.Кәримов

7) Бер үк хокукка, бер үк дәрәҗәгә ия булу. *Һәрхәлдә, синең хөкемеңә буйсынып, синең теләкләреңә белән килешеп, итагатьле хатын булып кына торуны аңардан көтүе читен, бик читен. Үзенә күрә түгел, ниндидер гаделлек, тигезлек сөюче ярлы бер тәкәббер бит ул!* Ә.Еники. *Балалар арасында да тигезлек бетте.* Ф.Җамалетдинова

8) *мат.* Ике математик зурлыкның бердәйлеген белдергән тамга, билге. *Плюс (+) һәм минус (–) билгеләре 1490 елдан гына кулланыла башлый, ә тигезлек билгесе (=) – 1557 елдан.* Сабантуй

9) *мат. к.* **бердәйлек** (*2 мәгъ.*). *Тигезлек билгесе белән тоташтырылган ике алгебраик аңлатма тигезлек төзи.* Алгебра

10) *геогр.* Зур тауларсыз, иңкүлекләрсез киң мәйдан биләгән җир өслеге. *Удмуртия Көнчыгыш Европа тигезлегенең Урал буе өлешендә урнашкан, монда калкулыклар һәм түбән төшкән җирләр аралашкан.* Б.Хәмидуллин

**ТИГЕЗЛЕ́-ТИГЕЗСЕЗ** *с.* **1.** Урыны-урыны яки вакыты-вакыты белән бик үк тигез булмаган. *Никадәр азапланырга туры килә иде аңа андагы тигезле-тигезсез ала-кола басуларда, чокыр-чакыр буйларында, урман куеннарында!* Н.Фәттах. --- *янгын каланчасы күләгәсенә елышып утырган каравыл өе дә бик нык үзгәргән: аскы бүрәнәләре сипләнеп, түбәсе тигезле-тигезсез такта белән яңартылган.* М.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрлечә, төрле рәвешчә; тигезлек сакламыйча. --- *мәктәп турысында беркадәр вакыт тигезле-тигезсез атлаган йөзләрчә тояк тавышлары --- ишетелеп торды.* Н.Фәттах. *Аңа тигезле-тигезсез итеп карандаш белән язылган.* Р.Мостафин

**ТИГЕ́ЗПОЧМАКЛЫ** *с. мат.* Барлык почмаклары да үзара тигез булган. *Тигезпочмаклы өчпочмакның периметрын табу*

**ТИГЕ́ЗПОЧМАКЛЫК** *и. мат.* Тигезпочмаклы геометрик фигура. *Тигезпочмаклыкның һәр ягы тигез булмаска да мөмкин. Әйтик, дүртпочмаклыкның.* Геометрия

**ТИГЕЗСЕЗ** *с.* **1.** 1) Өсйөзе тигез, такыр, шома булмаган. *Тигезсез юлдан як-якка чайкалгалап бара торгач, Горшков тагын туктарга кушты, машинадан төште ---.* Н.Фәттах. *Тегесе эшнең нидә икәнен тиз төшенде булса кирәк, шунда ук акланырга тотынды: – Бигрәк тигезсез җир бит, чокыр да чакыр, Хөсәенов абый.* Р.Миңнуллин

2) Озынлыгы, зурлыгы һ.б. сыйфатлары буенча бертигез, бертөрле булмаган. *Бөтен җанын актарып салырлык юлларны укыганда, ул, хат кисәген ике кулы белән чытырдатып тоткан килеш, тигезсез хәрефләр белән язылган мәрхәмәтсез юлларга керердәй булып, кәгазь битенә иелде.* А.Вергазов

3) Туры, төз булмаган

4) *к.* **тигезле-тигезсез**. *Суга кермәде, үзенең теле начар, сулышы тигезсез иде.* Г.Ибраһимов. *Әрҗәсенә төялешеп, көйсез машинаны тигезсез тавыш белән үкертеп, көч-хәл белән дигәндәй, кырга барып җиттек.* Ф.Җамалетдинова

5) *күч.* Тиң, бердәй, бер дәрәҗәдә булмаган. *Тигезсез мәхәббәт иде бу, ә андый гыйшыкның ачысы бәгырьне бигрәк тә нык талый икән.* М.Маликова. --- *башкорт, казакъ һәм үзбәкләр милли пролетариаты булган рус, украин һәм татар янында тигезсез һәм хокуксызрак булып чыга түгелме соң?!* Р.Мөхәммәдиев

6) *күч.* Гадел шартларда булмаган; көчләр, шартлар тигезлеге бозылган. *Солдатларны сугыш һөнәренә өйрәткән, теткәләнгән батальоны белән дошманның ике полкына каршылык күрсәткәндә кабат яраланган һәм тигезсез сугышта һушсыз хәлдә әсирлеккә эләккән.* Т.Әйди. *Бәкләр, йөзбашы, унбашлары урыс баскынчылары белән тигезсез бәрелешләрдә башларын салдылар.* Ф.Зариф

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Төрлечә; төрле рәвештә, бер уңай гына, бер рәвештә генә түгел. *Арыш басуы иртәгә кияү куенына керергә тиешле җиткән кыз кебек дулкынлана, тигезсез сулый, үзенең яшьлеге белән саубуллаша.* М.Мәһдиев. *Өйалды ишегеннән яланбашлы ир кеше чыкты, ул, Балкышны күрмәгәндәй, тигезсез атлап һәм авыр сулап, капкага таба узып китте.* М.Маликова

2) Гаделсез рәвештә, тигезлек принципларын сакламыйча. *Элек-электән җирдә байлар һәм ярлылар яшәгән. --- Дөнья яратылганда ук тигезсез яратылган.* М.Хәсәнов.

**ТИГЕЗСЕЗЛЕК** *и.* 1) Тигезсез (чокырлы-чакырлы, керентеле-чыгынтылы, кытыршы һ.б.ш.) булу хәле. --- *җирнең тигезсезлеге, сулыклар күплеге биредә яшәүчеләргә шактый мәшәкатьләр тудыра.* Татарстан яшьләре

2) Тигез булмаган урын. *Кыз, юл тигезсезлегеннән файдаланып, әле итәген өскәрәк тартты, әле кофтасының кендек турын ачарак төште.* Ф.Яруллин

3) *мат.* Санлы зурлыкларның берсе (бер төркеме) икенчесеннән (икенче төркемнән) зуррак яки кечерәк булуын күрсәткән математик тәгъбирләмә. *– Ярар алайса, – диде Әлфия. – Кайбер авыррак темаларны, әйтик, параметрлы тигезләмә һәм тигезсезлекләрне чишү кебекләрен генә өйрәтсәм инде, бик усал күренә, аның белән тарткалашып, ямьсезләшәсем килми.* Н.Көбәш. *Үзара > яки < тамгасы белән тоташтырылган ике сан яки алгебраик аңлатма тигезсезлек төзиләр.* Алгебра

4) Аерым күренешләрнең үсешендә, торышында булган аерма, төрлелек. *Бер телдә, әйтик, терлекчелек терминологиясе бик нык алга киткән ---. Икенче телдә исә нәкъ киресенчә. Телләрнең мондый тигезсезлекләре (алар кирәк фонетика, кирәк грамматика, кирәк лексика өлкәсендә күзәтелсен) тарихи сәбәпләр белән аңлатылалар.* Р.Әхмәтьянов. *Сәнгать үсешендәге тигезсезлек аның төрләре һәм жанрлары яссылыгында да күзәтелә.* К.Гыйззәтов

5) *күч.* Үзара тиң булмау күренеше, тиңсезлек; гаделсезлек. *Тормышта кайгы-хәсрәт, пычрак-шапшаклык, тигезсезлек болай да кирәгеннән артык күп.* М.Хәсәнов. *Мондый гаделсезлектән, тигезсезлектән, хаксызлыктан гаҗиз булган яшь күңел яхшы ук аңлый башлый: байлар кайда да шул, аларның барысын да комсызлык кешелексез итә; гади халык бөтен җирдә бер үк төрле шартларда көн күрә: изелә, --- тирен түгеп эшли, әмма тернәкләнә алмый ---.* Җ.Юныс

**ТИГЕ́ЗТИЗЛӘНЕШЛЕ** *с. физ.* Хәрәкәтләнү процессы вакытка пропорциональ рәвештә тизләнә бара торган; *русчасы*: **равноускоренный**. *Тигезтизләнешле --- хәрәкәтләрнең бик мөһим үзлекләрен ачып, Галилей динамикага --- нигез сала, дип була.* Фән һәм тел

**ТИГЕЗҮ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **тигерү**. *Гыйльманов, уч төбенә салган тозына бәрәңгесен тигезә-тигезә, сүзне ялгап китте.* Х.Камалов. *Ярмөхәммәт бу йөзне, бу күзләрне якыннан, бик якыннан күрде бит кайчандыр. Монысы хак. Бит чокырларына иреннәрен тигезгәне бар аның.* Р.Батулла

2) *к.* **тидерү** (*2 мәгъ.*). --- *кахан сакчылары кыз урлаучыларны куа барсалар да, якын килергә курыктылар, чөнки угыз мәргәннәре – оста мәргәннәр, очкан кошның күзенә тигезәләр.* М.Хәбибуллин. *Кара-каршы атышабыз. Ул исерек бит, бүтән тигезә алмады, ә мин аның муенына һәм, гафу итегез, касыгына тигездем.* М.Маликова

**Тигезә башлау** Тигезергә тотыну. *Ул Хөрминең иренен канат белән су тигезә башлады ---.* Р.Батулла

**Тигезә язу** Чак кына тигезми калу. *Батталов итле чәнечкесен Нәҗмиевнең борынына тигезә язып селтәп алды.* Ф.Садриев. *Алмачуарның маэмайда хәбәре юк, ул атлаган саен, борынын җиргә тигезә язып, сискәндергеч хәрәкәт белән алга иелә, бөтен тәне белән тартышып куя иде.* М.Маликова

**Тигезеп алу** Тиз арада тигезү; бер мәртәбә тигезү. *«Танышу хөрмәтенә, изге ата, күтәрик», – дидем. Теге карышмады, бетереп эчте. Зария иренен генә тигезеп алды ---.* Х.Камалов. *Бетекчесе кереп, кечкенә өстәл янына бөкләнеп утыргач, каурый каләмен чәченә тигезеп алды да Йосыф каханга карады.* М.Хәбибуллин

**Тигезеп карау** Сынау өчен тигезергә омтылу. *Самолёт, чыдатырмы икән дигән сыман, тәпиләрен бер-ике тапкыр тигезеп карады да, ныклыгына ышангач, җир буйлап йөгереп китте.* Р.Вәлиев. *Кыз, иелеп, учы белән су алды да иреннәренә тигезеп карады.* Г.Тарханова

**Тигезеп кую** Бер тапкыр тигезү. *Чәкештереп эчәләр, Сания иренен генә тигезеп куя.* Э.Яһудин. *Ширин чынаягына үрелде, чәе суынган иде, эчмәде, иреннәренә генә тигезеп куйды.* М.Әмирханов

**Тигезеп тору** Әле, хәзер тигезү; даими яки әледән-әле тигезү. *Хан ярасына ул ниндидер төнәтмәләр сөртте, бөркет каурые белән ханның канланып кипкән иреннәренә шифалы су тигезеп торды ---.* М.Хәбибуллин. *Әмир коры сөяккә калып, хаста булып ята. Иреннәренә каурый белән су тигезеп торалар.* В.Имамов

**ТИГЕ́ЗҮЗГӘРЕШЛЕ** *с. физ.* Хәрәкәтләнү процессы бер юнәлештә һәм вакытка пропорциональ рәвештә үзгәрә торган; *русчасы*: **равнопеременный**. *Әйләнә тирәли тигезүзгәрешле хәрәкәт*

**ТИГЕ́ЗЬЯКЛЫ** *с. мат.* Һәр ягы да үзара тигез булган; *русчасы*: **равносторонний**. *Алты шырпы ал каптан: Телмә дә, сындырма да, Тигезьяклы дүрт өчпочмак Шулардан ясап кара.* Р.Нуруллин. *Тимерчыбыктан һәр ягы 12 шәр см лы тигезьяклы өчпочмак ясалган.* Сабантуй

**ТИГЕ́ЗЬЯНЛЫ** *с. мат.* Ике ян ягы үзара тигез булган; *русчасы*: **равнобедренный**. *Радиусы R булган түгәрәккә камаулы тигезьянлы өчпочмаклардан мәйданы иң зур булганын табарга.*

Югары математика нигезләре. *Кояш, Юпитер һәм астероидлар төркеме галәмдә тигезьянлы өчпочмак хасил итә.* Фән һәм тел

**ТИ́ГЕЛЬ** *и. нем.* Эчендә металл һ.б.ш.ны эретү яки бик каты кыздыру өчен кулланыла торган, утка аеруча чыдам металлдан эшләнгән сыешлык. *Прибор үзе көл төсендәрәк булса да, хром-никельле регулятор-боргычлары, серле шкала, көмеш тигельләре белән ялтырап, кукыраеп утыра.* Э.Касыймов. *Бакыр тамчылары ябышкан тигель, күпсанлы бакыр пластинка кисәкләре, бакыр әйбер ватыклары һәм бакыр шлагы кисәкләре табылу монда бакырчы яшәгәнлеге һәм эшләгәнлеге турында сөйли.* С.Айдаров

**ТИГЕН** *с.* **1.** 1) Түләүсез бирелә, сатылмый торган. *Әгәр Айбулатка кичәлебүгенле якты чырай бирүе – тик торганнан тиген эш дип бер мөгез чыгаруы гына булса?* Т.Әйди. *Тиген киемгә тиенү*

2) *к.* **тикмә**. *Тиген кеше*

**2.** *рәв. мәгъ.* Бушлай, бушка. – *Тиген эләкте сиңа бу сәгать, – диде ул урамга чыккач, – затлы нәрсә, кадерен белеп саклап кына йөрт.* И.Гази

**3.** *и. мәгъ. бор.* Мөһер, келәймә, тамга. *Арзанлы металлар кушып ялган акча ясауга комачау итү өчен, дәүләт власте металл акчаларга келәймә суга башлый. Борынгы төрки телдә келәймә тиген дип аталган.* А.Тимергалин

**ТИГЕНГӘ** *рәв.* 1) *к.* **тиген 2.** *Машинаны тигенгә бирәләр дип уйладыңмыни?* Т.Миңнуллин. *Кун фуражкасын арткарак этәрде дә өзелгән әңгәмәсен ялгап китте: – Ә син беләсеңме, Хәкимҗан ага, Кадыйр Үзбәковка хәрәм ризык килешмәде, тигенгә ашаганнары яман шеш булып чыкты.* Н.Хәсәнов

2) Юкка, файдасызга. *Чапма, аякларың тигенгә кабармасын, --- акрын барсак та, максатка тиз җитәрбез.* Г.Коләхмәтов

◊ **Тигенгә калдыру** Җәзасыз калдыру, үчен алмау; буш калдыру, хакын кайтармау. *Тимәгәнгә тимә, тигәнне тиген калдырма.* Мәкаль

**ТИГЕРҮ** *ф. к.* **тидерү**. *Мин менә иртән тору белән, --- бакчама кереп, --- гөлләрем белән сөйләшәм, керфекләренә бармакларымны тигерәм ---.* Ф.Садриев. *Син нәрсә, понимаешь, суык тигереп чирләргә, сугыш чорында эш калдырып өйдә ятарга уйлыйсыңмы?* Н.Әхмәдиев

**Тигерә язу** Чак кына тигерми калу. *Джон сөлгене күкрәгенә кысты да, җиргә тигерә язып, башын өч мәртәбә иде, халыкка рәхмәт әйтте.* Ф.Садриев

**Тигереп алу** Тиз генә тигерү; бер мәртәбә тигерү. *Кыюрак яшүсмерләр кайсыдыр кызларның бит очларына иреннәрен дә тигереп алалар иде хәтта.* Ф.Баттал. *Ул да әтисе каршына тезләнде һәм аның битләренә, танырга теләгәндәй, бармак очларын тигереп алды, колакларын сыпырды.* Ф.Садриев

**Тигереп карау** Сынау-тикшерү өчен тигерү. *Шофёр, иң беренче эше итеп, кулын Мөниржанның маңгаена тигереп карады.* Н.Әхмәдиев. *Аннары, баш бармагын чалгы йөзенә тигереп карагач, аякларын аерып басты һәм, ачу белән селти-селти, киң пакус алып китте.* Р.Вәлиев

**Тигереп кую** Бер тапкыр тигерү. *Егетләр эчү «залпын» кабатладылар, кызлар да иреннәрен тигереп куйдылар.* Х.Камалов

**Тигереп тору** Әле, хәзер тигерү; даими яки әледән-әле тигерү. *Ә Зәлия аны үпте, иреннәрен озак итеп тигереп торды.* Х.Камалов

**Тигереп үтү** Тидереп китү, үтешли тигерү; аз гына, җиңелчә генә тигерү. *Алгы бүлмәдә калгыган сары кызгылт яктылык ашыкмый гына йокы бүлмәсенә узды, --- карчыкның йон оекбаш киеп өлгергән аякларына сарылды, тезләренә сикереп менде, чәчләрне тарап, түбән төшкән сөяк таракның асылташ кашына койрык очын тигереп үтте.* Л.Зөлкарнәй

**ТИДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тию** (*1–10, 16 мәгъ.*). *Соңра, күтәрелеп, бикәгә таба берничә атлады да, тагы үзе иелеп, сул тезен җиргә тидерде.* Г.Ибраһимов. *Рөстәм кайчакта, күңеле нечкәреп, иркә җан ияләрен кулына ала, йомшак мамыкларын битенә тидерә, ипине учына салып кулыннан ашата.* Ф.Яруллин

2) Мылтыктан һ.б.ш. җайланмалардан төз атып кирәк җиргә эләктерү, туры китерү. *Саша, чабып, урамга чыкты, килгән ягына бармакчы иде, пистолет тоткан берәү каршыга төште, Саша аңа атып җибәрсә дә тидерә алмады ---.* Р.Сәгъди. *Мин угымны агач башында утыручы тиеннең сул күзенә тидерә алам.* Аманулла

**Тидерә башлау** Тидерергә тотыну. *Тик, нигәдер, тешләрне генә берберсенә тидереп булмый. Тидерә башладыңмы, хәзер шакылдарга тотыналар.* В.Нуруллин

**Тидерә язу** Чак кына тидерми калу. *Хатын бусаганы атлауга, байбичәнең йөзенә туры карап, үзе бераз иелде, уң тезен җиргә тидерә язганчы бөкте.* Г.Ибраһимов. *Миңа әллә нәрсә булды: батыраеп, Гөлнәфидәнең «мәхәббәт чокыры»на иреннәремне тидерә яздым.* Г.Гыйльманов

**Тидереп алу** Тиз генә тидерү; бер тапкыр тидерү. *Салих, пошынып, минем күзләремә карады, аннары, аз гына икеләнгәннән соң, кулының сыртын маңгаема сак кына тидереп алды.* Ә.Еники. *– Мин ялган вәгъдәләрдән туйган, – дип, Сәет кулының кабыргасын муенына тидереп алды.* Т.Галиуллин

**Тидереп карау** Сынау-тикшерү өчен тидерү. *Тагы юләр мавыгуга бирелеп китеп, Тәүгиз беләгенә кызган кыскыч тидереп карады.* Х.Камалов. *Бервакыт ул хәтта бармагына буялган сөтне теленә дә тидереп карады.* Г.Рәхим

**Тидереп кую** Тиярлек хәлдә калдыру; бер тапкыр тидерү. *Халидә рюмкага авызын гына тидереп куя.* Ф.Яруллин. *Баязит кайнаган нервы, кызган баш белән ашыгып барды да, ялгышып, парашаны су кранына якын тидереп куйды.* Г.Ибраһимов

**Тидереп тору** Әле, хәзер тидерү; даими яки әледән-әле тидерү; билгеле вакыт тидергән хәлдә булу. *Ул үзүзеннән гафу үтенеп, ләүкәнең биегенә менеп, дулкын-дулкын чәчләрен күгелҗем юшкын ямьсезләгән түшәмгә тидереп торды.* А.Гыйләҗев. *– Чынлапмы? – диде һәм --- кинәт урыныннан кузгалды да, Сөенчалинга килеп, аның кулларын учына алды, бик каты кысты һәм битенә иреннәрен тидереп торды.* Х.Камалов

**Тидереп чыгу** Һәрберсенә бер-бер артлы тидерү. --- *Назирә коридор стенасыннан штукатурны --- тәмләп ашый иде: авызына шоколад каба да, шуны җебеткәч, буе белән коридор стенасына конфетлы иреннәрен тидереп чыга, аннан шул урыннарны ялый иде.* М.Мәһдиев. *Хәзер шул кәлтә койрыгын тот та шайтан таякларының чәчәкләренә тидереп чык.* Ф.Яруллин

**ТИЕЛГЕСЕЗ** *с.* 1) Кагылырга, рөхсәтсез алырга, орынырга (кулланырга яки сарыф итәргә) ярамый торган. *Ул гына түгел, ведомство хезмәткәрләре өчен «тиелгесез» статусына ия төбәкләр һәм оешмалар булган.* М.Котлыгаллямов. – *Юкка куркасыз, шәхси милек безнең илдә тиелгесез, закон сезнең яклы, – дип юатмакчы булдык.* Өмет

2) Кагылып булмый торган, кагылу мөмкин булмаган

**ТИЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тию**

2) Саксызлык, ялгышлык белән, очраклы рәвештә тию, кагылу. *Ялгыш буялган коймага тиелдем*

3) Тиеп, кагылып китәргә туры килү, тиеш булу. *Баланың тупрак өстенә тиелгән кечкенә тәпекәйләрен күргәнегездә, гүя бер фәрештә бу бишекнең эчендә калган дип әйтәсегез килмәсме?* Дәрдемәнд. *Ибтидаи мәктәпләр юк авылда да яңгыларны ачарга, барларын ислах итәргә, бөтен мәктәпләргә бер программа кабул итәргә карар чыгарылды. Аның берлән генә калмады, мәдрәсә мәсьәләсенә дә тиелде.* Г.Исхакый

4) Бетерелү, сарыф ителү. *Ерак та ерак иске тирмән --- Тиелми калган бу урман.* Н.Исәнбәт. *Кагылмаслык дип санала Шул җиремнең меңнән бере. Тиелмәскә дигән урман, Йогынмаска дигән таулар.* И.Киньябулатов

**ТИЕН** I *и. зоол.* **1.** Тиенчәләр семьялыгыннан агач куышларына оялап, чикләвек, бөреләр белән туклана торган, йомшак мехлы, йөнтәс озын койрыклы кимерүче җәнлек. *Йокыбай тавыш килгән якка чапкан. Барып җитсә, ни күзе белән күрсен: бер агач ботагы яртылаш сынган да тиеннең койрыгын кыскан икән.* Ф.Яруллин. *Урман аңа бөтен матурлыгын ачып җибәргән иде: тегендә-монда тиеннәр сикерешә.* С.Гаффарова

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлек тиресеннән эшләнгән. *Җәен-кышын ул --- кыска балаклы сырган чалбардан һәм тиен эчле каракүл бүректән йөри.* М.Галәү. *Рушан бер тәнәфестә өстенә матур тиен тун --- кигән зифа буйлы, тәбәнәк кенә кызны күреп алды.* Р.Мирхәйдәров

**ТИЕН** II *и.* 1) Сумның йөздән бер өлешенә тигез акча берәмлеге. *Ниндидер юл белән кулга төшергән биш тиенгә бер кием тишек башмак сатып алды ---.* М.Галәү. *Биш тиенгә, теге як ярга чыгып, ике стакан морс эчәргә була, аннары әле чөеп уйнарга да кала!* Ф.Хөсни

2) Вак акча, металл тәңкә. *Бакыр тиеннәр арасында сирәк-мирәк көмешләре дә күренә иде.* М.Хәбибуллин. – *Акчам юлга җитәрлек кенә, – диде Миңниса һәм кәшилүгеннән учына шалтыр-шолтыр тиеннәр койды.* Ф.Җамалетдинова

3) *күч.* Аз күләмдәге, җитми торган, гадәттә зур физик көч куеп табылган акча, байлык. *«Тик мондый бәхетләләр сирәк була», – диде миңа Җәгъфәр энекәш һәм авыр сулап куйды, үзенең дә газиз тиеннәреннән колак каккалаганы булган, күрәсең.* А.Тимергалин. *Ичмасам, үзем дә тиеннәргә генә эшлим, күпме ярдәм итә алам соң мин?* Г.Тарханова

4) *күч.* Арзанлы, кирәксез яки әһәмиятсез нәрсә. *Рәхәтең булмагач, дәүләт өч тиен ул.* Г.Исхакый. *Кешенең бәясе бу илдә элек тә тиенгә тормаган, киләчәктә дә тиене артуга ышаныч юк.* Ф.Яхин

◊ **Тиен дә тормау** Кемнең яки нәрсәнең кадере, әһәмияте, авторитеты булмау. *Илмираңны күрмәдем, дим Мансурга, авыр туфрагы җиңел булсын, аның турында авыз күтәреп сүз әйтмим. Әмма бу балдызкай базар көнне ике тиен тормый, дим.* Г.Әпсәләмов

**ТИЕНДЕРҮ** *ф.* Кемгә дә булса билгеле бер нәрсәне табу, булдыру, шуның белән тәэмин итү. *Максат – халыкны икмәккә тиендерү.* Р.Мөхәммәдиев. *Шыңгырдап торган йортлы, мунчалы итте, сыерга тиендерде.* Г.Галиева

**Тиендерә башлау** Тиендерүгә табан бару. *Ә язга килгәндә, синоптиклар, ул март аенда ук җылы көннәргә тиендерә башлаячак, диләр.* Татарстан яшьләре

**Тиендереп килү** Байтактан бирле тиендерү. *Менә инде соңгы берничә еллар буена сөткә дә иткә тиендереп килде аларны*

**Тиендереп тору** Даими, гел тиендерү. *Эчәр суга тиклем тиендереп тора ул аларны.* Ватаным Татарстан

**ТИЕНЛӘП** *рәв.* 1) Тиеннәр берәмлегенчә; тиен исәбе белән, тиеннәр рәвешендә. --- *кечкенә Тәлгать тә куллары догага күтәрде. Базарга дип килгән мөселман ирләр, хатын-кызлар, тиенләп, хәергә акча бирделәр.* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Берәмтекләп, аз-азлап. *Зәмзәмия ул артык сак яши, булганын тиенләп тота.* Л.Ихсанова

**ТИЕНЛЕК** *и.* **1.** Кыйммәте билгеле тиеннәргә тигез булган акча берәмлеге. --- *буш, бөтенләй буш, бары тик җилләр белән яңгырап, шыңгырдап торган сандыкның ак тукыма җәелгән төбендә бер өем бакыр биш тиенлекләр ята иде.* А.Хәлим. *Камалы бүрек эчендәге ике тиенлекләр өстенә, чыңлап, илле тиенлек көмеш төшеп ятты.* Н.Яһудин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кыйммәте билгеле тиен берәмлегенә тигез булган. *Егерме тиенлек көмеш мулланың чапан кесәсенә шуып төшкәч, икәүләп тагын дога кылдылар.* М.Галәү. *Файзулла баш астыннан чиккән янчык чыгарды, озын ябык бармаклары белән аның төбеннән алып, алтын төсле ялтырап торган өч тиенлек өр-яңа бакыр күрсәтте.* Г.Бәширов

2) Хакы билгеле тиен булган, күпмедер тиен торган, билгеле тиен бәрабәренә бирелә, сатыла яки эшләнә торган. *Тегендә үзе сыер тотмый икән, чөнки кышка печән әзерләүләр кыйбатка төшә: биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян буласы.* А.Тимергалин. *Беләмени алар без студент чактагы кызларның 1 сум 50 тиенлек чәчкәле күлмәк киеп кадерсез булып йөрүләрен?!* Ф.Баттал

3) Билгеле бәягә бирелгән кадәр, күпмедер акчага килгән хәтле. *Ахырдан,*

*өчәр тиенлек кызыл кесәлдән соң кофе эчәргә тотынгач кына, иренеп кенә, ашыйммы икән, ашамыйммы икән дип икеләнеп, котлет ашый торган курсисткаларны, гәзитәнең тәмәнә манып кына җиде тиенлек борщ ашый торган студентларны күрделәр.* Г.Исхакый

**ТИЕНҮ** *ф.* 1) Зур тырышлык белән ирешелгән әйбердән канәгатьләнү. *Абый --- гаиләсенә, иркенрәк яшәр өчен, йорт салып, бакчалар утыртып җибәрә, җиләк-җимешкә тиенә.* К.Миңлебаев

2) Нәрсәгә дә булса канәгатьләнерлек күләмдә ия булу. *Болай барса, без мәңге кадрларга тиенә алмаячакбыз.* М.Маликова. *Ул таш калада бик тиз тамыр җәя: фатирга тиенә, йорт сала, бала үрчетә...* Н.Гыйматдинова

**Тиенә башлау** Тиенү мөмкинлеге туу. *Уйлап карасаң, икмәккә туйганга да күп түгел. 1955 еллардан соң гына ипигә тиенә башладык ---.* Ф.Галиев. *Русиялеләр шулай ук торак мәйданына да тиенә башлаганнар: ике дистә ел элек бездә бер кешегә 16 квадрат метр торак туры килсә, хәзер – 23 квадрат метр.* Татарстан яшьләре

**Тиенеп алу** Бераз, күпмедер вакыт кына тиенү. *Анда ул күпмедер вакыт яшәп, бәхеткә тиенеп ала.* Н.Гыйматдинова

**Тиенеп бетү** Тәмам тиенү. *Заманча аяк киемнәренә һәркем тиенеп беткәч тә, табигатькә чыкканда, чабатасын кия иде ул.* Ф.Баттал

**Тиенеп җитү** *к.* **тиенеп бетү**. *--- сугыштан соң әле --- халкы ипигә дә тиенеп җитә алмаган илдә санаулы гына еллар эчендә коммунизм шартына туры килердәй нинди муллык тудырмак кирәк?* Татарстан яшьләре

**Тиенеп килү** Аз-азлап, акрынлап тиенү. *Чөнки директор зур кеше, ә укучы кечкенә; директор укымышлы, ә укучы әле белемнәргә тиенеп кенә килә; --- директор аксакал яки олы кеше, ә укучы – нибары бала.* Г.Рәхим

**Тиенеп китү** Ниндидер сәбәптән, этәргечтән соң кинәт тиенү. *Менә шуннан соң акчага тиенеп киттек*

**ТИЕ́НЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Кимерүчеләр отрядының тиеннәрне, йомраннарны, борындыкларны һ.б. ыругларны берләштергән семьялыгы; *русчасы*: **беличьи**. *Тиенчәләр семьялыгына 230 дан артык төр керә.* Биология

**ТИЕШ** *хәб. сүз* **1.** 1) Алдан килгән фигыль аңлаткан эш-гамәлнең, хәрәкәтнең, шөгыльнең башкарылуы мәҗбүри булуын белдерә. *– Минемчә, һәркем рәсем ясый белергә тиеш, – диде аңа Сафуанов.* А.Тимергалин. *Укытучы бит ул, башкаларда да тормышка аек караш тәрбияләргә тиеш.* М.Маликова

2) Фигыль аңлаткан эш-гамәлнең, хәрәкәтнең, шөгыльнең якынча чамаланган, планлаштырылган булуын, үтәлүе ихтимал булуын белдерә. *Киләсе көз уңыш бәйрәмендә туй булырга тиеш иде.* Г.Бәширов. *Солдатның әле тагын бер минут вакыты калган булырга тиеш.* Х.Ширмән

3) Фигыль аңлаткан эш-гамәлнең, хәрәкәтнең, шөгыльнең кирәклеген, зарурилыгын белдерә. *Әмма бер шарт куйган: туй бүләге итеп, рус патшасы җиде көн эчендә Казанда иң биек манара салырга тиеш булган.* М.Хәсәнов. *Бүгенге ассамблеяның тикшерергә тиеш булган төп мәсьәләсе Җир дип аталган кечкенә планета һәм андагы акылга ия дип әйтергә мөмкин булган җан ияләре турында иде.* Р.Мөхәммәдиев

4) Алдан килгән инфинитив яки исем фигыльдән аңлашылган кагыйдә, канун, устав яки башка таләпләргә туры килү кирәклеген белдерә. *Аңа бик мөһим нәрсәне хәл итәргә кирәк: тупка кемне кем итеп билгеләргә? Төзәүче үткен, зиһене тиз йөри торган кеше булырга тиеш.* Х.Камалов. *--- генерал Василевский яхшы эшли белә торган урынбасар да, бер үк вакытта оператив идарә начальнигы да булган кешене бик ныклап, җентекләп эзли. Ул кеше бик эшчән һәм белемле булырга тиеш.* З.Зәйнуллин

5) Фикернең, бәяләмәнең билгеле закончалык яки логика буенча гына уйлап әйтелгәнлеген, фараз итүне белдерә. *Урта буйлы, бик төз, җыйнак тыгыз гәүдәле, көч үзендә яман булырга тиеш, беләкләрендәге таштай мускуллары буын-буын калкып тора.* Ә.Еники. *Шәһәр башлыгы мәҗлеснең уртасында булырга тиеш иде, Козецкий, үчегеп, аны чакырмады.* А.Гыйләҗев

6) Кемнең дә булса каршында бурычлы булуны белдерә. *Егет исә кесәсенә тыгылды: – Мин ничә сум тиеш? – дип сорады.* Р.Мирхәйдәров. *Мин дәүләтнең бу кешеләргә бик күп тиеш икәнен белсәм дә, җавап бирә алмыйм.* Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кемнең дә булса өлешенә тигән, үзенә билгеләнгән яки шуңа лаек (гамәл, эш). *Бер яфрак та хилаф юлга төшми, һәр күбәләк тиеш эшен эшли – Шаклар катырлык.* Г.Афзал. *Еш кына сәнгатькәр адәм баласы тиеш бәхеттән өлешсез кала, шуңа күрә сакаллы сабыйларның маңгаенда – шеш, күз төбендә фонарь күгәреп торыр, ә җаннарында бетәшмәс яра...* А.Гыйләҗев

2) Кайтарыласы, биреләсе булып торган кемнең дә булса каршындагы бурыч, әҗәт. *Сәламәтлек саклауның хәлләре инде бүген үк шәптән түгел, чөнки быел ук тиеш акчаның яртысына якыны гына бирелә.* Безнең гәҗит. *Бөтен балаларның да тиеш күләмдә бирелгән ризыкны ашап бетермәве аларга артык ризык салынуын белдерми.* Шәһри Казан

3) Үтәлүе таләп ителгән, мәҗбүри эшләнәсе булган. *Тиеш эшебезне башкардык*

4) Кемгә дә булса тапшырырга аталган яки адресланган. *Бирелергә тиеш хатны тапшырдым*

5) *к.* **тиешле 1.** (*3 мәгъ.*). *Минем моңа кадәр кемнең кем икәне хакында уйланганым юк иде. Ә уйланырга, белергә кирәк икән. Үзеңә дошман тиеш кешеләрне яклап йөрмәс өчен дә белергә кирәк икән аны.* Ф.Латыйфи. *Аннан алар, чыбык очы булса да, безгә туган тиеш кешеләр.* А.Хәлим

**3.** *и. мәгъ.* 1) Исәпләнгән, чамаланган, билгеләнгән, билгеләп куелган күләм, зурлык. *Олпат гәүдә, киң кулбашлар, бишмәте астында да калкып торган күкрәк, көчле, юан аяк-куллар – бар да тиешеннән дә артык иде егеттә.* З.Зәйнуллин. *Кызның хәтере калды: – Мин җырлыйм, ә ул Йолдыз*

*дигәнегез акча алып ятамы? – Син дә буш калмассың. Тиешен бирербез.* Р.Габделхакова

2) Йөкләнгән бурыч. *Законны өнәмисең, Налоглар түләмисең. Ходавәнә, аңла шуны: Тиешен үтәмисең.* Р.Маннанов

**ТИЕШЕ́НЧӘ** *рәв.* 1) Таләп ителгәнчә, билгеле бер нормалар яки исәпләнгән зарурлык таләбенә җавап бирерлек итеп. *Бүген без комсомолка Кәримә Дулатованың тәртибен тикшерергә җыелдык. Материаллар тиешенчә тупланылган.* Ф.Яхин. *Тиешенчә эшкәртелгән яшел үлән басулары, болыннары һәм көтүлекләре булган хуҗалыкларның эшләре дә әйбәт бара.* М.Зарипов

2) Билгеле бер максатка ярашлы рәвештә, кирәгенчә. *Куштанлыгы да бар: начальство авылга килгән чакларында тиешенчә каршы алып, тиешенчә кунак итеп җибәрә белә.* В.Нуруллин

3) Җиренә җиткереп, шартына китереп, тулы күләмдә, яхшы, шәп итеп. *Законнарның тиешенчә эшләнмәгәнлеге аркасында мәдәният өлкәсендә бик зур югалтуларга дучар булуыбыз ихтимал.* С.Ибраһимова. *Казан ханнары Мәхмүт һәм Мөхәммәт-Әминнең дә, алар тирәсендә табылган ике хатын-кыз җәсәде дә тиешенчә җирләнергә тиеш.* Сөембикә

4) Теләгәнчә, өмет иткәнчә. *Кеше бервакытта да үзенең ми сәләтеннән тиешенчә файдаланмый икән.* М.Мәһдиев

**ТИЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) *к.* **тиеш 2.** (*1 мәгъ.*). *Безнең йортта яшәүче әллә кемнәр әллә нинди юллар табып телефон керттеләр, әмма чиратсыз куелырга тиешле телефонны Мәҗит күрә алмады.* Ф.Яруллин. *Синең мин белмәгән, ләкин миңа сөйләргә тиешле сүзләрең бар кебек.* Ф.Садриев

2) *к.* **тиеш 2.** (*3 мәгъ.*). *Җыелышлар, көтелмәгән борчулар, әллә каян гына килеп чыккан, тиз хәл ителергә тиешле мәсьәләләр көнне төнгә, төнне көнгә ашыктырып алмаштырдылар.* М.Мәһдиев

3) Кемгәдер билгеле бер мөнәсәбәттә булган, шуңа бәйләнешле булган. *Җизни тиешле кешенең дә кәефе кырылды.* Г.Галиев. *Үз көнен үзе күрсен дип, атасы аны, туганрак тиешле сәүдәгәргә ияртеп, Бохарага озата.* Т.Галиуллин

4) Ниндидер эш, процесс дәвам итсен өчен ихтыяҗ булган, кирәкле. *Ярый, әти, Миронычның бу хаты турында мин иртәгә үк тиешле кешеләр белән сөйләшермен.* Т.Гыйззәт. *Хәсьянов белә: әгәр дә тиешле документлары булмаса, Нури карт саламны башкаларга түгел, Мидхәтнең үзенә дә бирмәячәк.* Н.Әхмәдиев // Кирәк күләмдәге, кирәк кадәр булган. *Мөнирҗан, алган әйберләрен сумкасына тутыргач, тиешле акчасын түләп, чыгышка юнәлде.* Н.Әхмәдиев

5) Канәгатьләндерерлек, югары дәрәҗәдәге. *Татар халык поэзиясенең үзенчәлеге һәм аның җыйналу тарихына тиешле фәнни анализ ясалган программа нигезендә Х.Бәдигый --- фольклористика курсын да алып бара.* Х.Ярми. *Тиешле белеме дә, сәүдә эшендә тәҗрибәсе дә булмаган хатынны мөдир итеп эшкә алу үзе үк шик уятырлык нәрсә иде.* А.Тимергалин

6) Лаеклы, урынлы, хаклы, гадел; ярашлы, яраклы. *Яңа килгән «кунак»ны алар тиешле хөрмәт күрсәтеп каршы алдылар.* Г.Әпсәләмов. *Ул каушабрак калды, тиешле сүз таба алмыйча ыкмык итте.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ. к.* **тиеш 3.** (*1 мәгъ.*). *Без – фән кешеләре, үзебез яшәгән елларга түгел (үзенә тиешлесен юләр дә яши), юбилейларда эшләгән хезмәтебезгә йомгак ясарга, киләчәккә зарядка алырга тиешбез.* Г.Әпсәләмов. *Директорыгыз кушканны үтәсәң, прокурор хатынына тиешлесен биреп җибәрсәң, кала идеңме бу хәлгә?* А.Гыйләҗев

**3.** *хәб. сүз мәгъ. к.* **тиеш 1.** (*1 мәгъ.*). *Каберләр ригаять кылынырга вә хөрмәтле тотылырга тиешле.* А.Тимергалин. *Көтмәгәндә малайның зиһене яктырып куйды: «Алтынчы таякчык мин үзем булырга тиешле». Алтынчы таякчыкка ул үзен тәгаенләде.* А.Хәлим

**ТИЕШЛЕК** *и.* Тиеш булу хәле. *Бу кыен мизгелдән котылу өчен, ул тагын бер чынаяк чәй ясамакчы булды, мин инде бүтән сүз озайтмаска тиешлегемне аңлаган идем, рәхмәт әйтеп урынымнан тордым һәм хушлашып чыгып та киттем.* Ф.Садриев

**ТИЕШЛЕ́-ТИЕШСЕЗ** *с.* 1) Урынлы-урынсыз, кирәксез; тиешенчә тикшерелмәгән, нигезләнмәгән. *Әйе, ул хәзер тиешле-тиешсез әмәлләр белән үзен күрсәтергә, район нәчәлникләре каршында абруй казанырга тырышачак.* Ф.Садриев. *Әмма аннан соң беркайчан да мин сиңа тиешле-тиешсез сораулар биреп аптыратмадым.* М.Кәбиров

2) Ни житте шундый, теләсә нинди. *Тик, матри, адәм көлдереп йөрмә, тиешле-тиешсез кеше белән, бигрәк тә азгын хатын-кыз белән чуалма.* А.Гыйләҗев

**ТИЕШСЕЗ** *с.* **1.** 1) Тиеш булмаган, урынсыз; кирәксез. *Тиешсез урында көләсең килсә, баш бармагыңның тырнагына кара.* М.Мәһдиев

2) Белергә, күрергә, ишетергә ярамаган, тыелган. *Бәгъзы бер ирләр хатыннарга юлда каршы чыгарлар вә дивар ярыкларыннан карап, тиешсез җирләрен күрергә тырышырлар иде.* Г.Буби. *Тиешсез җиргә тыкшынып йөрергә ярата торган гадәтең бар шул синең, Зәки.* В.Нуруллин. *Тиешсез сукмакка керәсең икән, эзеңне калдырма.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бирәүгә тиеш, лаек булмаган нәрсә. *Булдыра алган урында ул [Шәмгун] тиешлесен дә, тиешсезен дә басып калды.* А.Шамов. *Тиешлесен сорарга баруым лабаса. Тиешсезен таләп итүем түгел. Нәфесен тыя алмаган, дип, бирәү дә авыз чайкамас, шәт иншалла!* Р.Низамиев

2) Урынсыз, кирәкмәгән нәрсә; мәгънәсез нәрсә. *Без тиешсезне әйтмәбез.* М.Җәлил. *Чәчәкле чаршаулар --- өйгә ямь дә биреп тора, шул ук вакытта тиешсезен ят күзләр дә күрми: теләсәң ачып, кирәк вакытта ябып куясың.* Ф.Бәйрәмова

3) Тиешле таләпләргә җавап бирми торган, кирәксез кемсә. *Начар хәбәр әшәке ис кебек: күз ачып йомганчы таралып, тиешлесенә дә, тиешсезенә дә барып җитә.* Ж.Рәхимов

**ТИЕШСЕЗГӘ** *рәв.* Урынсыз, сәбәпсез, мәгънәсез рәвештә; тиеш булмаганча. *Солтан эшне озакка сузып боламык измәс өчен: – Була, Шөкер дус,*

*син әйткәч, без җир читенә барырга да риза, – дип, тиешсезгә көлеп куйды.* Г.Ахунов. *Әлбәттә, Хәнәфинең аларга карата гаделсез чаклары, кайбер очракларда хәтта тиешсезгә кимсеткән көннәре дә булгандыр.* В.Нуруллин

**ТИЕШСЕНҮ** *ф.* Нинди дә булса гамәлне үтәүне бурыч итеп санау. *Кулланган ишарәтләрем хакында изах бирүне тиешсенәм.* М.Фәйзи. *Без рузаның хәзергәчә дәвам итеп килгән хәленә разыймыз һәм шулай дәвам итүен тиешсенәбез.* Туган як

**ТИҖАРӘТ** *и. гар. иск.* Сәүдә, сату итү, товар әйләнеше процессы. *Кайсы кешеләр бу картны хәдсез-төпсез байлыгы вә һәр тарафларга канатын җәйгән киң тиҗарәте өчен олуглаганнары шикелле, кайсылар бабайның кунакка каршы булган ачык йөзе вә икмәк-тозы өчен тәгъзыйм итәләр иде.* Г.Тукай

**ТИҖАРӘТХАНӘ** *и. гар.-фар. иск.* 1) Сәүдә йорты, бик күп сату нокталары булган зур кибет. *Мәскәүдә мөселман каракүлчеләренең, оешып, мал алыр өчен, яңа тиҗарәтханә ачулары гәзитәбездә язылып үткән иде.* Г.Исхакый. *Әүвәл Истанбулның һичбер җирендә телефон юк иде, хәзер хөкүмәт даирәләре һәм политсә идарәләренең һәркайсында телефоннар булган шикелле, зур тиҗарәтханәләрнең дә һәркайсында телефоннар бар.* Г.Камал

2) Биржа

**ТИЗ** *рәв.* 1) Зур тизлек белән, бик кызу, ашыгыч. *Алда чокыррак җир, кинәт сукмак түбәнгә төшеп китә, менә шул төштән бик тиз йөгереп үтергә кирәк.* Х.Камалов. *Мин әлегә аларны, шушы су суалчаннарын, бу кадәр дә җәһәт һәм тиз йөзәләр икән дип башыма да китермәгән идем.* Ф.Яхин

2) Чагыштырмача аз, кыска вакыт эчендә. *Тополь – бик әрсез, тиз үсә торган мул ябалдашлы талымсыз агач.* М.Галиев. *Ашыгыч ярдәм һәм оператив төркем бик тиз килеп җитә.* Н.Вахитов

3) Якын арада, бераздан, кыска вакыттан соң. *Состав тиз китәсе булса, [кондукторлар] шунда, вагон кырында гына йөренгәләп торалар.* М.Мәһдиев

4) Шунда ук, кыска вакытта һәм кирәгенчә. *Галиулланың тел төбен Сабир тиз сизеп алды ---.* А.Алиш. *Зөфәр үзе дә сыңар куллы майорның аңа ничек каравын бик тиз белеп алды, әмма артык гаҗәпләнмәде ---.* Ә.Еники

5) Вакыт үткәне сизелмичә. *Җәй бик тиз үтте.* Ф.Садриев. *Яшь гомер тиз уза, картайган көнемдә япа-ялгыз калсам, нишләрмен?* Р.Хәбибуллина

6) Җитәрлек вакыт, сәбәп, этәргеч булмый торып; кинәт. *Нишләп әле ул бу чибәр егетнең һәр сүзенә бик тиз ышанды?* Г.Галиева. *Һәрхәлдә, ул күбесен яхшы белә: кемдер сабыр холыклы, кемдер тиз кабынып китүчән.* Р.Кәрами

7) Шундук; тоткарланмыйча, көттермичә. *Кызлар, тиз әйтегез, кайсыгызның утыз җиденче размер итальянский туфли киясе килә?* М.Мәһдиев. *Атасына ул, тиз кайтам, диеп чынын әйтсә дә, вәгъдәсендә тора алмады.* Р.Батулла

8) Йөгерек, ашыгыч. *Безнең бригада шулкадәр ашлык үстерде, тиз генә исәпләп тә чыга алмассың.* Г.Бәширов

9) Җәһәт; бик кызу, кызулап. *[Гафифә:] Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям. [Вәли:] Ну, бар, зинһар, тиз бул!* Г.Камал. *Әбисе күкәйләр әрчеп, Тозга ук манып тора, Тагын да тизрәк булсын дип, Шәвәли кабып тора!* Ш.Галиев

10) Ашыгыч рәвештә. *Шулай, Роза, сиңа китәргә, бик тиз китәргә туры килер.* А.Алиш

11) Янау төсмере белән: каты, кырыс, катгый, таләпчән итеп. *Син бит җиргә хәтәр татар булып туган. Дәүләтчелек нигезләрен какшата дип, Тиз утырта акылыңа «олы туган».* С.Әхмәтҗанова

◊ **Тиз кайтучан** Бик тиз ачуланып кызып китсә дә, ачуын тиз онытучан. **Тиз кулга** *к.* **тиз кулдан**. *Миңсылу тиз кулга керосинкада бер-ике таба төче коймак та салып алды.* К.Тинчурин. **Тиз кулдан** Ашыгып, бик җентекләмичә, тәфсилләмичә генә. *Тиз кулдан гына язган лозунглар, юлбашчыларның май демонстрациясеннән калган портретларын күтәргәннәр, шуларны баш өсләрендә тибрәтә-тибрәтә, нигәдер бик ашыгып атлыйлар.* Ә.Еники. *--- такталардан тиз кулдан өстәл сыман нәрсә корыштырганнар.* Х.Камалов. **Тиз тоту** Тиз, кыска арада башкару, эшләп чыгу. *Председатель булып килгәч, ул эшне тиз тотты: ике ай дигәндә алты почмаклы якты йорт җиткезделәр.* А.Гыйләҗев. *Малайларының: «Әти кайтты!» – дип шатланып кычкырганы --- ишетелде. Ләкин әниләре аларны тиз тотты: «Җитте!» – дип, бер генә эндәште дә, барсы да тынып калды.* М.Кәбиров. **Тиз төчкерү** Зурлап тотынган эштән кыска вакыт эчендә гайрәте чигү

**ТИ́ЗАТКЫЧ** *с.* Гадәттәгедән тизрәк, еш-еш ата торган. *Немецлар* **---** *йөзләгән тизаткыч тупларыннан шрапнель яудыра башладылар.* А.Таһиров

**ТИ́ЗӘЙТКЕЧ** *и. фольк.* Халык иҗатының әйтү өчен катлаулы сүзләрдән торган, тел шомарту күнекмәсе буларак кулланылган, кызыклы, шаян эчтәлекле кыска жанры. *--- мәкальләр гел-гелән сүзләр яңгырашы якынлыгына корылмаган, халык иҗатында сүзләр яңгырашы якынлыгы өчен башка жанрлар бар – тизәйткечләр, такмаклар...* М.Хуҗин. *--- без балалар бакчасында, ана телен үстерү максаты белән, татарча мультфильмнар күрсәтәбез, халык уеннары уйнатабыз, тизәйткечләр өйрәтәбез.* Татарстан яшьләре

**ТИЗӘК** *и.* 1) Организмда эшкәртелгән азыкның каты яки ярымсыек хәлдәге бүлендеге; экскремент, тәрәт. *Бу капка тирәсендә көнозын тавыклар тирес тарана, каз-үрдәк, күркәләр йөри, тизәкләре белән бөтен ишегалдын пычратып, ду килеп бозаулар чабыша.* М.Галәү. *Бу бит ашаганны тизәккә әйләндереп ятучы гына.* Р.Сәгъди

2) Ягулык буларак кулланыла торган кипкән терлек экскременты яисә махсус калыпка салып кирпеч кебек итеп сугып киптерелгән тирес; кизәк. *Бу – һәр көн кояш белән бергә кузгалып, --- сыерын, биясен сава, самавыр куя, --- даладан кипкән тизәк җыя ---.* Г.Ибраһимов. *Монда син медик булачаксың, авылда тизәк изәчәксең, гомер буена юньле эш табалмый акчасыз утырачаксың.* З.Мурсиев

**ТИЗӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тизәк, экскремент бүлеп чыгару

2) Тизәк белән пычрату, тизәккә батыру. *Ул кяферләрдән берсе килеп көймәне тизәкләгәндә, егылып, тәненә тизәк тиде.* К.Насыйри. *Хәтта дуңгыз яткан җирен тизәкләми, Усал эт тә хуҗасына карап өрми.* Р.Ханнанов

3) Тизәк белән ашлау, тиресләү

**ТИЗГЕР** *с. диал.* Өлгер, җитез, җәһәт. *Һәйкәл --- ишкәкле каекта талгын Идел буйлап ашыкмыйча гына ил гизүчеләрне һәм тизгер электропоезд юлаучыларын да ерактан ук сәламли.* А.Тимергалин

**ТИЗГЕРЛЕК** *и. диал.* Тизгер булу; җитезлек, өлгерлек. *Ринатның тизгерлеге сокланырлык инде, күз генә тимәсен*

**ТИЗДӘН** *рәв.* 1) Хәзерге мизгелдән яки сөйләнгән, әйтелгән мизгелдән соң озак та тормыйча; озакламыйча. *Свастикалы бер немец танкысы аеруча ачык күренә, чөнки ул алгы сызык янында ук шартлатылган. Ул хәзер бөтенләй кәкрәеп, җиргә сеңеп бара: тиздән сазлык аны бөтенләй йотачак.* Г.Әпсәләмов. *Тиздән беренче кар күренер, бу сары яфраклар, черек алмалар кар астында калырлар.* Ф.Садриев

2) Чагыштырмача кыска вакыт үткәч тә, тиз арада, тиз көндә. *Тиздән, бәлки, бүген үк, Галләм килә.* М.Фәйзи. *Зиннәт әлегә белми: тиздән, бик тиздән – бүгенме, иртәгәме – аның каршына баласын җитәкләгән бер яшь хатын килеп басачак ---.* Г.Гыйльманов

**ТИ́ЗЙӨРЕШЛЕ** *с. тех.* Тиз йөри торган, югары тизлекле. *Ерак Көнчыгышка Владивосток шәһәренә юл тотарга тиешле тизйөрешле поезд менәменә кузгалып китәчәк икән.* С.Сабиров. *Крейсер, чылбырларын шыгырдатып, якорен төпкә җибәрүгә, ярдан шундук тизйөрешле зур катер кузгалды.* А.Хәсәнов

**ТИЗЛӘНЕШ** *и.* 1) Гадәттәгедән тизрәк барлыкка килү, булу, башкарылу күренеше, тизлекнең эзлекле рәвештә арта баруы. *Димәк, сез тизләнеш, стресслар тулы тормышыбызда кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең, шул исәптән җенси мөнәсәбәтләрнең дә, ата-бабаларыбыздан килгән әхлак кануннарына – кешелеклелек сыйфатларына нигезләнергә тиешлегенә басым ясыйсыз.* Сөембикә. *Көйнең темпы никадәр тизрәк булса, этәрү шулкадәр көчлерәк. Темпның тизләнеше арткан саен, ул сүрәнәя ---.* Татар фольклористикасы

2) *физ.* Тизлекнең вакыт берәмлегендә үзгәреше. *Тизлекнең үзгәрү кызулыгын тизләнеш дип аталган зурлык белән күрсәтәләр.* Физика курсы. *--- бауга бәйләп маятник ясыйсың да, шул маятникны аста һәм түбәдә чайкалдырып, авырлык көче тизләнешенең аермасы буенча биеклекне исәплисең.* К.Шакиров

3) *икът.* 1985 елда Советлар Союзында хезмәт дисциплинасын ныгыту һәм житештерү куәтләрен интенсив эксплуатацияләү хисабына игълан ителгән социаль-икътисади үсеш курсы; үзгәртеп коруның бер юнәлеше. *– Безнең колхозда тизләнеш, үзгәртеп коруларның мәңге булачагы юк! – дип кычкыра торгач, Фәргать кичә карлыгып туктаган иде.* Ф.Садриев. *Михаил Горбачёвка 80 яшь тулган көннәрдә узган гасырның сиксәненче еллары уртасында килеп чыккан «үзгәртеп кору», «кеше факторы», «тизләнеш» дигән төшенчәләргә икътисади, социаль һәм әхлакый бәя бирергә тырышу активлашып алды.* Кызыл таң

**ТИЗЛӘНЕШЛЕ** *с.* Тизләнеше булган, тизләнеш белән барган

**ТИЗЛӘНЕШСЕЗ** *с.* Тизләнеше булмаган

**ТИЗЛӘНҮ** *ф.* Тизлеген арттыру, кызулану. *Республикада балалар бакчалары төзү темпы бик нык тизләнә.* М.Хәсәнов. *Көннәрнең берсендә егетләр кинәт уянып киткән кебек булдылар, хәрәкәтләре тизләнде.* Р.Сәгъди

**Тизләнә бару** Торган саен тагын да тизләнү. *Ул арада машина, тизләнә барып, Кызыл тау түбәсенә җитте.* Р.Батулла. *Уйлары уянган саен, адымнары тизләнә барды.* М.Кәбиров

**Тизләнә башлау** Тизләнү билгеләре сизелү, күренү. *Бу чорда япон мәдәнияте үсүе тизләнә башлый*

**Тизләнә төшү** Тагы да тизләнү. *Атлавы да рәхәт булып китте. Җилкәләр күтәрелә, адымнар тизләнә төште.* И.Беляев. *Шуннан соң элемтә урнаштырганда, Заһитның яралануы һәм санбатка әләгүе белән вакыйгалар кура, тизләнә төшә.* С.Маннапов

**Тизләнеп алу** Бераз, күпмедер вакытка тизләнү

**Тизләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә тизләнү. *Буа суының өсте җылымса, чумсаң – астан бәреп чыккан чишмәләрнең салкынлыгын тоясың. Кан йөреше тизләнеп китә, тәнгә көч керә.* В.Юныс

**ТИЗЛӘТЕЛГӘН** *с.* Интенсив чаралар кулланылган, гадәттәгедән тизрәк үтәлә, башкарыла торган. *Ул ун көн эчендә илнең бөтен икътисадын, --- милли мәсьәләнең ни дәрәҗәдә һәм кем файдасына хәл ителүен, --- сәнгатьнең торышын һ.б.ны барлык чыганаклар буенча тизләтелгән метод белән өйрәнергә ниятләде.* А.Тимергалин

**ТИЗЛӘТЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **тизләтү**. *Фролов әз генә тизләтелгән эш темпы бирә, аңардан калышырга оят була башлый.* Х.Камалов. *Менә марш ахырына якынлашты, ритмнар тизләтелде, такт көчәйде ---.* Г.Гомәр

**Тизләтелә төшү** Бераз тизләтелү. *Мөхәммәдәмин, беренче адымнарыннан ук, ханлыгының бу яңа – икенче этабында да элек башлаган эшен тагын да тизләтелә төшкән темп белән дәвам иттерә.* М.Гайнетдин

**ТИЗЛӘТЕП** *рәв. сөйл.* Бик тиз генә, ашыгыч рәвештә. *Хатлар яздым тизләтеп. Сөйгәнемне күзәтеп.* М.Җәлил. *Тизләтеп килеп җитәргә кирәк*

**ТИЗЛӘТКЕЧ** *и. тех.* Нинди дә булса бер процессны, хәрәкәтне тизләтә торган җайланма. *1968 елда мине яңа төзеләчәк --- үтә куәтле гамма установка һәм электрон тизләткечләр белән җиһазланган --- цехка җитәкче итеп билгеләделәр.* Р.Зарипов. *Дөньяда иң көчле – зур андрон тизләткеч ясау идеясен Америка физигы Франклин Фелбер чын-чынлап практик максатларда кулланырга тәкъдим итә.* Шәһри Казан

**ТИЗЛӘТҮ** *ф.* 1) Хәрәкәтнең яки процессның тизлеген махсус рәвештә арттыру, интенсивлаштыру, кызулату. *Поручик Мөхәммәтҗан Хөсәенов илле ике атлы гусар белән --- биш чакрым чамасы араны атларын юыртып җылытты да аннан соң тизләтеп куа*

*башлады.* З.Зәйнуллин. *Артта кала башлауларын сизеп алгач, адымнарын тизләтеп, чананы куып җитәләр дә яңадан үрмәлиләр.* Г.Әдһәм

2) Ашыктыру; тизрәк ясарга, булдырырга, тәмамларга тырышу. *Стабилизатор канатларын калибрлап өлгертә алмау аңарда, шушы эшне тизләтү өчен, бер-бер нәрсә уйлап табу теләген уятты.* Г.Әпсәләмов. *Талия, сиңа ирең белән аерылышуны ничек тә тизләтергә кирәк булачак, икең дә риза булганда, аны тиз хәл итәләр.* Г.Галиева

**Тизләтә бару** Торган саен тизләтү. *Рөстәм --- автобус артыннан атлады, аның белән бергә адымнарын тизләтә барды һәм йөгерүгә күчте.* М.Кәбиров

**Тизләтә башлау** Тизләтергә тотыну. *Ул аның каушавын тойса да, нәкъ шулай булыр дип күз алдына китергән һәм күңеленә күптән керткәнлеге сәбәпледер – адымнарын тизләтә башлады.* Ф.Яхин

**Тизләтә тору** Тизләтүен дәвам итү. *Күбрәк элеккеге дәверләргә караган ачыктан-ачык юк итү, төрле геноцидлар булмаганда да, ассимиляция дигән нәрсә кала килә. Глобальләшү дигән шаукым, авторитаризм басымы, шовинизм аны тизләтә торалар.* Н.Шәрифуллин

**Тизләтә төшү** Бераз тизләтү; тагын да тизләтү. *Бу сүзнең мәгънәсен дөяләр дә аңлады булса кирәк: алар да, муеннарын алгарак сузып, ялкау адымнарын тизләтә төштеләр.* М.Галәү

**Тизләтеп алу** Бераз, берара тизләтү. *Кичке аштан соң саф һавада йөрергә чыккан җиреннән, инде ярыйдыр дип уйлап, адымнарын тизләтеп алды* ---. Ф.Тарханова

**Тизләтеп җибәрү** Кинәт тизләтү. *Кайчакларда бу үзгәреш өчен адымыңны тизләтеп җибәрү дә җитә кала.* Ф.Тарханова

**Тизләтеп карау** Сынау-тикшерү өчен тизләтү

**ТИЗЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Тизрәк бара, йөгерә яки йөри башлау. *Хатын серне аңлады, күл буенча камышка таба тизләп йөгерде: анда, --- иярле атлар янында, берничә колакчын торганы күренә иде.* Г.Ибраһимов. *Хәрби тормышка өйрәнгән күндәм малкай хуҗасыннан бер адым да калышмый барды. Хуҗасы ешласа, ул да тизләде, йөгерсә, ул да юыртты.* Ш.Шәйдуллин

2) Тиз генә башкарып, эшләп чыгарга тырышу; ашыгу, кабалану. *Гөлсем, күзе күзгә очрамасын өчен, башын иде, тизләп, култыклап, исерек ирен алып китмәкче булды.* Г.Исхакый. *Әле кичә үзенең көзге йөзен кул яссуы кадәр генә күрсәткән су бүген, елан сыман, без эшли торган урынга үрмәли. Ул тизләгән саен, без дә тизлибез.* А.Алиш

**Тизли бару** Торган саен тизләү. *Нинаның әти-әниләре аны шунда ук күреп алдылар һәм, мөгаен, поездның тизләгәннән-тизли баруына шатланганнардыр да әле.* Р.Мирхәйдәров

**Тизли төшү** Тагы да бераз тизләү. *--- юл буйлап бер автомобиль чаба. Без тиз барабыз, ул да тиз бара. Поезд тагын да тизли, автомобиль дә тизли төшә.* А.Алиш

**ТИЗЛЕК** *и.* 1) Хәрәкәт итү, үсү, озаю, күбәю, таралу һ.б.ш. күренешләрнең вакытка нисбәтән бару, башкарылу дәрәҗәсе. *Шул чакта болытлар арасыннан, карчыгалар кебек, күз иярмәс тизлек белән атылып, безнең кызыл йолдызлы штурмовиклар килеп чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Гитлер гаскәрләре анда безнең берничә армияне камап алалар һәм зур тизлек белән юк итәргә тотыналар.* З.Зәйнуллин

2) *физ.* Җисем үткән юл озынлыгының шул юлны үтүгә киткән вакытка нисбәте. *--- поездыбыз боргалана-сыргалана әле елга ярыннан, әле Альп калкулыклары сыртыннан йөгерә, әмма уртача тизлеге йөз чакрымнан һич тә кимеми* ---. Т.Әйди

3) Билгеле бер нәрсәнең хәрәкәтенә охшаган яки билгеле бәяләү системасы, үлчәү шкаласына карата башкарылу дәрәҗәсе. *Моның берәр очы-ахыры булырдыр бит дип, кибернетик тизлектә фикер йөрткән арада, ни күрим: алда – биек трамплин!* К.Миңлебаев. *Поезд яктыргач гына кузгалып китте. Аның юлда хәрәкәтләнүе ташбака тизлеге белән бер, кечкенә станцияләрдә дә хәтсез озак тора.* Ф.Хуҗин

4) Кызулык, өлгерлек, елгырлык, җитезлек. *Башкалар аптырабрак торган арада, Марат, сугышырга җыенгандай, җилтерәп барды һәм, күз иярмәс тизлек белән әләктереп, җилкәсенә үк күтәрде дә, --- хатынын арткы бүлмәгә алып чыгып китте.* Ә.Баян. *Менә поши --- аякларын тирәде дә хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнде. Аннан соң, зур тизлек белән, бер тоннага якын гәүдәсен дошманына ыргытты.* И.Хуҗин // Җәһәтлек, ашыгычлык. *Обер-лейтенант әфәнде, барыгыз, бу җитди мәсьәләне тизлек белән чишегез.* Т.Гыйззәт. *Рәхилә бик тизлек белән (хәтта шундый тизлек белән, әйтерсең йөрәге тибүеннән туктап тора иде) кәгазьне укырга керeште* ---. Ә.Баян

5) *тех.* Транспорт берәмлекләренең махсус җайланма белән үзгәртелә торган тарту көче. *Танк зур тизлеккә күчеп элдерде генә.* Х.Камалов // Машина һәм механизмнарда механик хәрәкәтнең билгеле бер вакыт берәмлегенә нисбәтән юл үтү дәрәҗәсе. *Кузгалып киткәч тә, ул беренче тизлек белән генә барды, аннары икенчегә күчте. Мотор бик әйбәт, бик көйле эшләде.* Н.Фәттах. *Шул чакны урам чатыннан ниндидер күләгә аерылды да икенче тизлектә борыла-сырыла сөйрәлгән машина артыннан кача-поса килә башлады.* А.Вергазов

**ТИЗЛЕКТӘ** *рәв. иск.* Бик тиз, ашыгыч рәвештә, тиз арада, кыска вакыт эчендә. *Тизлектә монда килмәсәң, минем түзәр хәлем калмады.* Ф.Әмирхан

**ТИ́З-ТИЗ** *рәв.* 1) Бер-бер артлы күп хәрәкәтләр ясап башкарыла торган эш-хәрәкәт яки шөгыль-процесс турында: бик тиз, бик җәһәт; кызу ритм белән, кызу темпта. *--- ул урман юлыннан тиз-тиз монда таба атлап килүче Сабитны күрде.* А.Гыйләҗев. *Авызына су керсә, эт тиз-тиз йөзә башлый ---.* В.Имамов

2) Ашыгыч рәвештә; ашыгып, кабаланып. *Карт шундый итеп акырды ки, гомерендә бу хәтлене ишетмәгән карчыгы аякларына тиз-тиз генә киезкаталарын эләктерде дә, ах-ух килеп, карт артыннан йөгерергә керeште.* Ә.Баян. *--- иртән авылларыннан шалтыратып, Җәүһәрнең әтисе авырганлыгын хәбәр иттеләр. Җәүһәр, ут*

*капкандай, тиз-тиз җыенып чыгып китте*. Ф.Яруллин

**ТИК** I *рәв.* 1) Хәрәкәтсез, тыныч. *Фәридә күзләрен читкә борды, нәрсәсендер рәтләмәкче булды, нииндидер хәрәкәт ясамакчы булды, ләкин берни эшли алмады: каршысына бүре килеп чыккан бәрән сыман, куркып-калтыранып тик утырды.* Н.Фәттах. *Бәләкәй булгач, аны уенга катнаштырмаганнар, тик торып туңып беткән, бичарам.* Л.Ихсанова

2) Бер көе, һаман бер рәвештә. *Исле сабын белән бик матурлап битен юып, чаршау артында чәчен тарап үрә дә, мәрҗәннәрен асып, көмеш балдакларын киеп, чулпыларын чылтыратып, тик йөри бөтен өйне балкытып.* Г.Бәширов. *Элек бала уенчык ала иде дә бер почмакта мыштым гына тик уйнап утыра иде.* Ш.Галиев

3) Болай гына, эшсез, эшләмичә, буш; максатсыз. *Тордым да, гадәтем буенча, һичбер эшсез, тик йөрер өчен, иренеп кенә урман араларына чыгып киттем.* Гали Рәхим. – *Безнең председатель дә тик йөргәнне яратмый!* – *диде Бибинур.* А.Гыйләҗев

4) *сөйл.* «Ник» соравына каршы әйтелә торган кире мәгънәле сүз. – *Ник болай иттең?* – *Тик*

◊ **Тиктән тик** Бер дә сәбәпсез, максатсыз, эш юктан гына. *Читтән бер өстәлдә писарьлар, стена буенда тиктән тик карап торган чабаталы түрәләр бар иде.* М.Фәйзи. **Тик торганда** 1) Сәбәпсез. *Нигә тик торганда тавыш чыгарасыз?* М.Мәһдиев. *Тик торганда танадай тәкәне егып суюы әллә ничек бит.* С.Сабиров; 2) Көтмәгәндә, искәрмәстән. *Базар көнне ничек кенә булса да Миңлебикәне очратырга кирәк иде. Ләкин ничек, тик торганда, бер кызга: «Әйдә, минем хатын буласыңмы?» – дип әйтәсең.* М.Мәһдиев. *Шулчак, тик торганда гына, дәрья дулкынлана, кайный башлады.* Р.Батулла. **Тик торганнан** *к.* **тик торганда**. *Чыннан да, ничек инде тик торганнан үз акчаңны башкаларга чыгарып бирәсең ди.* Р.Миңнуллин. *Шулай дидем дә тик торганнан өстәп куйдым: – Абдрахман олатаем да сугышта башын салган, уф, өч олатаем булып та, ичмасам, берсен дә күрмәдем!* Г.Якупова. **Тик тормау** Кирәкмәгәнгә, урынсызга активлык күрсәтү; сабырсызлану. *«Ватан» пионерлары --- телләре тик тормау аркасында, эшне харап итеп ташладылар.* Г.Гобәй. **Тик торыштан** *к.* **тик торганда**. *Насрый тәмәке тартып утыра иде. – Кызганыч, мескеннәр... Тик торыштан тормышлары бозылырга мөмкин... – диде.* Ш.Камал. **Тик тоту** 1) Нәрсәне булса да игътибарсыз яки хәрәкәтсез калдыру. *Мин шул үрдәк, телен тик тотмау аркасында, үзен дә һәлак итә язган, хуҗасын да бәлагә төшергән.* А.Алиш. *Хатын-кыз күргәч, кулларыңны тик тоталмаганыңны барыбыз да беләбез, мулла абзый.* Д.Салихов; 2) Эштән читтә тоту, эшләтмәү. *Монда тик тотмыйлар, төрле эшкә җигәләр икән.* С.Сабиров. **Тик ятмау** Чара күрү. *Дөрес, Вилдан Гыйльманович, безне товар ягыннан алай кысмыйлар, ләкин без үзебез дә тик ятмыйбыз: эзлибез, табабыз, кыскасы, завод халкын ничек тә яхшырак тәэмин итәргә тырышабыз.* Ә.Еники. **Тик яту** Озак вакыт эшләми яшәү. *Чөгендерчеләрнең бер отышлы ягы бар: кыш буена өйдә тик яталар.* Г.Якупова

**ТИК** II *терк.* **1.** 1) Җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне бер-беренә каршы куя; ләкин, әмма. *Татар халкы борынборыннан «Кешеләрдән кешеләр һич ким түгел, тик бәхеткәйләре тиң түгел» дип белми җырламагандыр.* Т.Галиуллин. *Әмма чеби, колагына да элмичә, һаман менәргә маташа икән, тик максатына гына ирешә алмый.* Ф.Яхин

2) Мөстәкыйль җөмләнең башында килә һәм алдагы җөмләгә каршы куя. *Әркәшә, Зарифуллин, Гыйззәтуллин, моны күреп, тораташ булып каттылар. Тик Әлтафи гына дөрләгән күңелләргә салкын су сипте: – Артистлар астан кулларын тыгып уйнаталар аларны, – диде ул, бер дә исе китмичә генә.* М.Мәһдиев. *Офыкта болытлар тартылган, тик бер бәйләм нур һаман җанны җылытып, күренеп тора иде.* А.Гыйләҗев

3) Беренче җөмләдәге фикерне чикләү мәгънәсен белдерә; шулай да, шуңа карамастан. – *Рәхмәт, Шәмгыя, килгәнсең, укыйсың, тик мәнә фәлән җирендә ялгыштың, менә болай дөрес була, – дип, «Ясин» сүрәсен үзе дәвам итте.* А.Хәйртдинова. *Бераз гына соңлап килгәнсең, билгеле, тик ни эшләмәк кирәк, шулай язган булгач.* Р.Гаязетдин

4) Җөмлә башында алмашлык, теркәгеч яки мөнәсәбәтле сүзләр белән килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Тик ничаклы гына күрергә тырышса да, тышта көлсыман аксыллыктан башка нәрсә шәйләмәде.* Ш.Бикчурин. *Тик никадәр тәмле дисәң дә, миләш – миләш инде, артык күп ашый алмыйсың.* Г.Бәйрәмова

**2.** *кис. мәгъ.* Бары, фәкать, гына. *И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм.* Г.Тукай. *Болай яшәү рәвеше начар булмаска тиеш аның. Башында бүрек, өстендә якалы пальто. Тик шул зәп-зәңгәр күзләрендә генә тетрәндергеч сагыш, моң сизелә. Әнисез булганга инде.* А.Хәсәнов

**ТИК** III *бәйл. иск.* Кебек, шикелле; тиң. *Сәгатьләре ай тик, көне ел тик Син җаныкаемның дәртеннән.* Җыр. *Бу учреждениедә хөрмә талыдай зифа буйлы, кояш тик нурлы йөзле бер егет курьер булып хезмәт итәр иде.* Ә.Исхак

**ТИК** IV *и. голл.* Тыгыз сугылган мамык тукыма төре (урын-җир әйберләренә тышлык тегү өчен кулланыла)

**ТИК** V *и. малаял. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан Көньяк һәм Көньяк-көнчыгыш Азиянең муссонлы урманнарында үсә торган, табигый төсе сары, һавада үзлегеннән көрәнәя барган кыйммәтле каты үзагачлы агач. *Корыч ныклыгындагы өлгеләрен ул төрле кыйтгалардан юнәткән. Әйтик, Бирмадан – тик агачы, Сикоку утравыннан – япон нараты, --- Панаманы үткәндә – тис.* М.Галиев

**ТИКӘН** *и.* 1) Кайбер үсемлекләрдә булган очлы, нечкә, каты чыгынты; чәнечке, энә. *Әй былбыл, тикәннән гөлне аера бел.* Дәрдеменд

2) Сабагында шундый чәнечкеләр күп булган үсемлек. *Усал кигәвен дә газиз монда, тикәннәр дә назлы күренәләр.* Р.Кожевникова

**ТИКӘНЛЕ** *с.* Тикәннәре булган, чәнечкеле, энәле. *Шайтан таягы дигән тикәнле үсемлекне руслар татарин/татарник дип тә, мордвинник дип тә йөрткәннәр.* А.Тимергалин

**ТИКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Текелдәү. *Ә сәгать дигәнең бертуктаусыз үзенең тикелдәвен белә.* Г.Бәширов. *Пыяласына капланып яткач кына йөри ала торган будильникның өстәлдәге буш калай кружкага чиртеп тикелдәвен ишек дөбердәве күмде ---.* К.Кәримов

**Тикелдәп алу** Бераз, күпмедер вакыт тикелдәү

**Тикелдәп кую** Кинәт тикелдәү; бер тапкыр тикелдәү. *Өстәлдә сәгать тикелдәп куйды*

**Тикелдәп тору** Әле, хәзер текелдәү; даими яки әледән-әле текелдәү

**Тикелди башлау** Тикелдәргә тотыну. *Диләрәнең кулындагы сәгате тикелди башлады*

**ТИККӘ** *рәв.* 1) Юкка, бушка; кирәкмәгәнгә, әрәмгә. *Кеше үз гомерендә бер генә агач утыртып үстерсә дә, тиккә яшәмәгән, диләр.* Ф.Яруллин. *Әнә бит тирә-якта күпме агач тиккә аунап ята.* С.Шәрипов

2) Бер сәбәпсез, нигезсез; максатсыз. *Тиле тиккә кызар.* Мәкаль. *Адәм баласы тиккә генә сәфәр чыкмый.* А.Гыйләҗев. *– Белмәгәнең юк, тиккә бригадир итеп куймаганнар икән үзеңне, – дип, шапылдатып, Ихтыярның җилкәсенә сугып куйды председатель.* Р.Вәлиев

**ТИКЛЕ** *терк.* Кадәр, кадәрле, хәтле, чаклы. *Кысыр сыер җилене тикле күчтәнәч кыстырып, җәй буе атасы хисабына тамак үткәрергә кайтып төште.* А.Гыйләҗев. *Класстагы укучылар гына түгел, хәтта кара такта янына элengән карта каршында безгә дәрес аңлатып торган укытучыбыз Галия апага тикле сискәнеп китте.* В.Нуруллин

**ТИКЛЕМ** *терк. к.* **тикле**. *Моңа тиклем алдынгылыкны беркемгә дә бирмәгән сыер савучы Мөсфирә кара көнләшү белән янды ---.* Х.Ибраһим. *Аның шул тиклем надан булуына әйтерсең лә китап бите гаепле.* С.Зыятдинова

**ТИКМӘ** *с.* Гади, ни җитте, игътибарга лаексыз. *Таш чыгаручылар: «Тикмә таш түгелдер бу, бер-бер хикмәте бардыр», – дип шигәя үк башлагач, минем бабай йөрәксенеп әйтеп салмасынмы ---.* А.Гыйләҗев

**ТИ́КМӘГӘ** *рәв. к.* **тиккә**. *Мәрдәнша агай тикмәгә генә кызмады.* Н.Фәттах. *Хакимнең олы башын кече итеп редакциягә керүе дә тикмәгә генә түгел, аның күңелен корт кимерә иде.* Н.Гыйматдинова

**ТИКМӘ́-ТИК** *рәв. к.* **тикмә-тиккә**. *Тикмә-тик йөреп тору. Тикмә-тик көлеп җибәрү*

**ТИКМӘ́-ТИККӘ** *рәв.* Сәбәпсез, тик торганнан, һич кирәкмәгәнгә, һич юкка. *Һәрхәлдә, мин тикмә-тиккә елмаймыйм.* Ш.Әхмәдиев

**ТИ́КТӘСКӘ** *рәв. диал. к.* **тикмәгә**. *Я дөнья, нигә болай син? Әле күзгә борылганын беркем белми, тик бакчадагы шомырт агачы бүген инде тиктәскә генә бер-ике яфрагын саргайтып куйды ---.* М.Мәһдиев. *Таш йөрәген әдип йөрәгенә Алмаштырып юкка, тиктәскә, үзен генә түгел, башкаларны Интектерә күпме иптәшләр?* Н.Нәҗми

**ТИ́КТОМАЛГА** *рәв.* 1) Тик торганнан. *Башының артынарак киелгән кәләпүше егетнең мөселман икәнен күрсәтеп торганга күрә, Хәят анасының бу портретны күрсәтүе тиктомалга түгел икәнен сизенде ---.* Ф.Әмирхан. *Болай тиктомалга әрле-бирле йөренеп булмый бит инде, шикләнүләре бар.* М.Хәсәнов

2) Һич көтмәгәндә, һич сәбәпсез; дуамалланып. *Тиктомалга бәйләнә, кемгә генә дәшсә дә, авызында эт җиймәс әшәке сүз иде бу конарсызның.* Р.Кәрами

**ТИ́КТОМАЛДАН** *рәв. к.* **тиктомалга**. *Кәрим аның ни өчен болай тиктомалдан кайтырга җыенуын аңламады.* М.Галәү. *Кеше тиктомалдан шушы төсле ябыкмый, дәрткә бирелгән бу.* Ф.Садриев

**ТИКТОРМАС** *с.* 1) Тынгысыз, хәрәкәтчән; сабырсыз. *--- җитез аяклы тиктормас кәҗәләр, яшьрәк агачларның йомшак кайрыларын кимерә-кимерә, көтүнең алгы сафында баралар ---.* М.Галәү. *Ындыр арты урамында тагын бер Әхәт абый бар иде. Анысын Борча Әхәт дип йөрттеләр. Кечкенәдән үк ут борчасы кебек тиктормас, елгыр, җитез, үткен, хәрәкәтчән булганга, шундый кушамат такканнар.* Р.Кәрами

2) Ял белми торган; уңган, эшчән. *Әби баядан бирле картының эшне онытуына кыйналып йөри икән ләбаса. Аһ, бу дөнья куучы җитмешне тутырган тиктормас карчыклар!* Т.Әйди

**ТИ́КТОРЫШ** *и. физ.* Хәрәкәтсезлек. *Җир һәм башка күк җисемнәре шул ук атом дәрәҗәсендәге кисәкчәләр генә булгач, аларның да тикторыш халәтендә массасы була алмый лабаса!* Ж.Юныс. *Әгәр дә йөк үзенең авырлык үзәге төшмәслек урында урнаштырылса, һичшиксез, йөк бу урында тикторыш халәтендә булачак.* Фән һәм тел

**ТИКШЕРГЕЧ** *и.* Контроль ясау, тикшерү, берәр нәрсә эзләү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Ә имтихан бирергә керер алдыннан металл тикшергеч аша үтеп, камера астында утырган бала нилəр кичергән дип уйлыйсыз?* Татарстан яшьләре

**ТИКШЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тикшерү**. *Киңәшмәдә тикшерелгән яңа проект буенча, вакытлы буа эшләтү һаман да Булатовка йөкләтелде.* А.Алиш. *Рыкаловның эше һаман тикшерелә, кайчан бетәсе дә билгеле түгел.* Г.Әпсәләмов

2) Врачта каралу. *Алар ел саен тулы медицина тикшерүе уза: төрле белгечләрдә тикшерелә, анализлар тапшыра.* Өмет

**ТИКШЕРЕНҮ** I *ф.* 1) Кызыксынып күзәтү, сорашу; тотып карау. *Сарычәч --- кибеттәге бөтен нәрсәне тотып карый, тикшеренә. Ыштансыз ревизор.* Ф.Яруллин. *Гүя Марфа карчык --- әллә нигә дип почмакларны карый, нәрсәдер эзли-эзләнә, тикшеренә ---.* Ф.Яхин

2) Фәнни алымнар, тәҗрибәләр ярдәмендә кызыксындырган чынбарлык һәм иҗат күренешләренең асылын, төзелешен, сәбәпле бәйләнешләрен ачыклау. *Бер колхозда сөтнең куелыгы югары икән. Галимнәр тикшеренә, нәрсәдә хикмәт: нәселдәме? Төбәкнең үзенчәлегендәме*? Ш.Галиев. *Җиде ел элек мине Германиягә Макс Планк фәнни тикшеренү институтына эшкә чакырдылар ---.* Р.Зарипов

3) Берәр нәрсә турында бик вакчылланып, бәйләнеп төпченү, әйтелгәнгә ышанмыйча, башка чаралар белән җентекләп күзәтү. *Солдатлар --- чекрәеп, тикшеренеп карап торган башлыкларның зәһәрле күз карашлары астында --- сафка тезелеп, алга юнәлделәр.* М.Гафури. *Һии, Нәҗимов, Нәҗимов, юкка мәшәкатьләнеп йөрмә! Мин – Радик абыегыз хатыны. Кем минем өстән тикшеренеп йөрергә батырчылык итсен?* В.Нуруллин

4) *сөйл. к.* **тикшерелү** (*2 мәгъ.*). *Берниндди баш авыртуга да түзеп йөрергә ярамый, һичшиксез табибта тикшеренеп, сәбәбен ачыкларга һәм кичекмәстән дәвалана башларга кирәк.* Мәдәни җомга

**Тикшеренә башлау** Тикшеренергә тотыну. *Җиткерүче булган, ахрысы, бер кибеткә халык контроле килеп, тикшеренә башлый ---.* Ш.Галиев. *Берәр егетнең үзенә күңеле төшкәнен сизде исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип, тикшеренә башлый ---.* М.Маликова

**Тикшеренә тору** Шактый вакыт тикшеренү. *Егет үзе турында берни әйтмәсә дә, сораша-тикшеренә торгач, барыбер үзенә кирәген белде Рәйхана.* Р.Габделхакова. *Кәгазьнең аскы кырында дүртпочмаклы борынгы пичәт тә бар. Тикшеренә торгач, «Ибраима царя жалованная грамота» дигән сүзләр табыла.* М.Госманов

**Тикшеренеп карау** Сынау максаты белән тикшеренү. *Әллә соң тикшеренеп карарагамы, бәлки, чынлап та, инвалид группасы бирерләр ---.* Р.Габделхакова. *Сәламәтлек үзәгендә тикшеренеп карарга теләге булган кешедән нибары паспорт, мәҗбүри медицина иминияте полисы гына сорала.* Татарстан яшьләре

**Тикшеренеп йөрү** Тикшеренү хәлендә булу. *Безнең нәселебездә юк ул кысырлык! Әгәр тикшеренеп йөрсәм, бөтен авыл миннән кычкырып көләчәк.* Г.Галиева

**Тикшеренеп тору** Даими, әледәнәле тикшеренү. *Йөкле хатыннарыгыздан авыр эш эшләтмәгез, фельдшерларга гына булса да күренеп, тикшеренеп торсыннар дип, әз тукыйбызмыни без сезгә?!* М.Маликова. *Европа илләрендә бала, туганнан башлап, бер табибта эзлекле тикшеренеп тора.* Л.Зәйнуллина

**ТИКШЕРЕНҮ** II *и.* 1) Камилрәк алымнар табарга, яңарак, уңышлырак ачышлар ясарга омтылып, озак вакытлар берәр нәрсә өстендә алып барылган эш; берәр фән өлкәсендә тикшерү эше, эзләнүләр. *1961 елдан бирле эзләнүләрем, нәкъ менә шушы остазымның фатихасы белән башланып киткән тикшеренүләрем Ракета гаскәрләрендә өр-яңа бер юнәлеш булып, хәрби өлкәдә дә үзенчәлекле әһәмияткә ия иде.* З.Зәйнуллин. *Француз психологы Мишель Гоклен астрологик прогнозларның ялган булуын исбат итәргә ниятли, ләкин аның тикшеренүләре һич тә көтелмәгән нәтиҗәгә китерәләр.* А.Тимергалин

2) Алып барылган эшнең нәтиҗәсен ачыклаган, чагылдырылган фәнни хезмәт. *Миңнуллин иҗатына багышлап әллә ничаклы әтрафлы хезмәтләр, хәтта киң колачлы монографик тикшеренүләр язылган.* М.Вәлиев. *Тукаебызның 100 еллыгы уңае белән байтак тикшеренүләр, фәнни хезмәтләр басылды ---.* Л.Гарипова

**ТИКШЕРЕНҮЧӘН** *с.* 1) Кирәкмәгәнгә яки усаллашып, үч итеп тикшерергә, төпченергә яратучан. *Тикшеренүчән түрә белән эшләү*

2) Күзәтүчән, сынаучан. *Озын буйлы, озын чәчле егетләр шау-гөр киләләр һәм минут саен диярлек кызлар ягына сынаулы һәм тикшеренүчән, әмма болай карап торырга игътибарсыз күренгән караш ташлыйлар.* Р.Сибат. *Рамиләнең әтисе – ут сүндереп йөреп кызысланып беткән кеше – тикшеренүчән карашларын миңа төби.* Р.Рахман

**ТИКШЕРЕНҮЧЕ** *и.* Фәнни тикшеренү белән шөгыльләнүче белгеч. *Кайбер тикшеренүчеләр, андагы баш сөякләренең берничәсе славянныкы түгел, дип кистереп әйтсәләр дә, ул бәхетсез башларны татар башы дип игълан итәргә берәү дә базмый.* А.Тимергалин. *Без Европадан Байкалга чаклы, Мәскәү юнәлешендә Ока елгасына кадәр төрки атамалар очратабыз. Бу хакта тикшеренүче Э.М.Морзаевның «Төрки географик исемнәр» дип аталган китабы бар.* З.Мурсиев

**ТИКШЕРТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тикшерү**. *Син сөйләгәннәрне полковник Галимов тикшертте, бар да дөрес.* З.Зәйнуллин. *Хәрби трибунал архивы аша тикшерттек.* А.Хәсәнов

**Тикшертә башлау** Тикшертергә тотыну. *Яхшылап торып тикшертә башласак, бик тиз табачакбыз без ул сарыкларның кая киткәнен!* В.Нуруллин. *Озак кына хаты килми торды. Яраланган булган икән. Ничек ул алай, дип военкоматтан тикшертә башлагач кына, серне әйттеләр.* Ф.Садриев

**Тикшертеп алу** Тиз генә тикшертү; бер тапкыр тикшертү. *Чир-мазарлары юк, шикләнмәгез. Без аларны бүген генә әле тикшертеп алдык. Чиста кызлар.* Р.Сәгъди. *Алай да март аенда йөрәгегезне тикшертеп алу зыян итмәс ---.* Шәһри Казан

**Тикшертеп йөрү** Озак вакыт дәвамында тикшертү. *Пенсияне яңадан чутлатып, тикшертеп йөри торгач, пенсиям 2300 сумга артты.* Татарстан яшьләре

**Тикшертеп карау** Сынау максаты белән тикшертү. *Көктугайга кайткач та, ул икенче бригаданың җир сөрү турындагы барлык мәгълүматларын яңадан тикшертеп карамакчы булды.* Н.Фәттах. *Ул вакытта Чиләбе больницасында да тикшертеп караган идем авыл халкының авыру тарихын, дөресен әйтмәделәр, анализларын бирмәделәр.* Ф.Бәйрәмова

**Тикшертеп тору** Һәрвакыт, әледәнәле тикшертү. *Хатын-кыз өчен тешләрне тикшертеп тору бигрәк тә әһәмиятле.* М.Мәһдиев. *Әледән-әле врачка күренеп, сәламәтлекне тикшертеп тору беркемгә дә зыян итми.* М.Маликова

**Тикшертеп чыгу** Рәттән барысын да тикшертү. *Башкортстанның барлык район загсларына хатлар язып, сугыш алды елларында булган барлык катнаш никахларны тикшертеп чыктым.* Р.Мостафин

**ТИКШЕРҮ** I *ф.* 1) Махсус сорашу, сынап карау, эзләнү, күзәтүләр аша кирәкле мәгълүмат алырга тырышу;

тәфтиш итү. *Өстә, түшәмгә терәлеп, тар озынча тәрәзә кебек ачыклык сузылган, һәр әсирнең беренче төп уе ничек тә качу җаен карау булганлыктан, шунда ук бер-берсе өстенә тырнашып менә-менә, теге ачыклыкны тикшерделәр.* Х.Камалов. *Ә сез аңа шул ук җинаятьләрне тикшерергә, ачарга кушасыз.* Т.Әйди. *Көндәлегең белән танышып чыккач, улым, күңелемдә шикләр уянды: синең үлемең очраклы гына булмагандыр, күрәсең. Мин моны тикшерәчәкмен әле.* Ф.Яруллин // Билгеле бер урында нәрсәләр барын җентекләп карап, ачыклау, аныклау. *Туктап ял иткән вакытта, алар әйләнә-тирәгә күз салалар, тикшерәләр һәм, бу урын яшәү өчен әйбәт җир булырга охшый, дигән нәтиҗәгә киләләр.* Ф.Гарипова. *Файдалы казылмаларны тикшерү өчен кирәкле «Зонд белән нокталы электромагнит тикшерү методы базасында углеводородларны геологик тикшерү аппаратурасы» дигән проект турында ул тулырак сөйләде.* Шәһри Казан

2) Берәр объектның, эшнең торышын ачыклау өчен, махсус рәсми тикшеренү үткәрү. *Без җиденче трестның финанс-икътисади хәлен җентекләп тикшерәбез.* Т.Галиуллин. *Узган ел республикадагы барлык автомәктәпләрне 856 мәртәбә тикшердек.* Р.Мөхәммәдова // Нәрсәнең дә булса дөресләгеннн, кагыйдәгә туры килгәнлеген, законлылыгын һ.б. ачыклау. *Ак «Жигули»ны туктатканнар да йөртүченең кәгазьләрен тикшерәләр.* Т.Галиуллин. *Алар һәр кешенең билетын һәм документларын җентекләп тикшерәләр иде.* Ф.Бәйрәмова

3) Кемне яки нәрсәне дә булса барлау, барлыгын-юклыгын ачыклау. *Иртәгә безне кем тикшереп йөри? Чортым да тикшерми.* Ф.Хөсни. *Рамазанның әйберләрен барлап-тикшереп йөрүче дә юк.* Л.Гыймадиева

4) Фәнни ысуллар белән өйрәнү, анализлау; тикшеренү. *Бер көнне безгә бер кызны китерделәр һәм сәламәтлеген тикшерергә куштылар. Тикшердек. Ул таза-сау --- иде.* М.Маликова. *Казанышларыбыз олы, һәр көн космосны тикшерүдә, дәвалау өлкәсендә, авыл хуҗалыгында, промышленностьта, --- җәмгыятьнең алга китүе өчен яңа эзләнүләр алып баруда уңыш арты уңыш китерә.* Казан утлары

5) Берәр нәрсәнең дөреслеген, төзеклеген, яхшы, уңай яки җитешсез, кире яклары барлыгын ачыклап карап чыгу. *Иншаны ике укытучы тикшерәчәк икән. Бу – тыныш билгеләре һәм орфографик хаталарны җентекләп тикшерү максатында эшләнә.* А.Закирова

6) Нәрсәне дә булса дикъкать белән карау, күзәтү, аның аерым якларына игътибарны юнәлтү. *Мин кияүгә чыкканда, булачак иремнең анасын да, атасын да, туганнарын да тикшереп тормадым, Атластан башкалар мине борчымый иде.* Р.Габделхакова. *Ул вакытта --- премьераны карарга ярты Казан килә торган иде: ким дигәндә биш-алты язучы, бөтен тәнкыйтьчеләр, мәдәният институтыннан, Фәннәр академиясеннән белгечләр. Анда һәрбер сүзеңне, һәрбер хәрәкәтеңне тикшерәләр, энә күзеннән үткәрәләр иде.* Р.Сабыр

7) Махсус оешма, комиссия кебекләрнең утырышында, җыелышында карау, фикер алышу. *Беренчедән, комиссиягә килеп кергән закон проектларының барысын да регламент кушканча өйрәндек, комиссияләрдә тикшердек, сессияләргә тәкъдим иттек, кабул иттек.* Р.Миңнуллин. *«Без бу эшне болай гына калдыра алмыйбыз! – дип зәһәр чәчте класс җитәкчесе. – Фәлинә, иртәгә үк --- без аны педсоветта тикшерәчәкбез».* Г.Рәхим

8) *сөйл.* Гаепләп сөйләү, яманлау. *Кызык кына бу кешеләр, Хәнифә апа, үзләренекен күрмиләр, кеше бот арасын тикшерәләр.* Х.Туфан. *Кем булдыгыз атагызны тикшерергә? Ыштан киеп өлгерделәр дә аталарын тикшерәләр.* Т.Миңнуллин

9) *сөйл.* Берәр кешенең артыннан күзәтү, күз-колак булу, шымчылык белән шөгыльләнү. *Инде күптәннән пенсия яшендә булып та, кирәксә-кирәкмәсә дә бөтен җиргә тыгылып, кырларның сыйфатын тикшерәсе урынга, күбрәк кеше тикшереп йөргән Фәйзи, Бибинур җенен үз күзе белән барып күрергә --- ният итте.* Х.Ибраһим

**Тикшерә бару** Рәттән, һәрберсен тикшерү. *Каюмда кисәк кенә шундый фикер туды: кайткач, Ләләгә дә индивидуаль эш бирергә. Һәм көндәлек үтәлешен тикшерә барырга.* М.Мәһдиев

**Тикшерә башлау** Тикшерергә тотыну. --- *Мансур урындыкка утырды, авыруның кулын тотып, тамыр тибешен тикшерә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ул акрын гына исемлек тикшерә башлады.* М.Мәһдиев

**Тикшерә бирү** Бернәрсәгә игътибар итмичә, тикшерүне дәвам итү. *Ләкин үзсүзле Галимҗан һич тә аптырап калмый, кашларын җыера да: «Тикшерә бирсеннәр», – дип, «патша»лардан калмыйча, стадионга бара.* Җ.Мостафин

**Тикшерә тору** Тикшерүне дәвам итү. *Тикшерә торгач, кайбер исемнәр грекныкы да, латинныкы да түгел, бәлки төркиләрнеке булып чыга.* Н.Фәттах. *Көртлек атканда да, урманга утынга барса да, үзе гел тирә-якны күзләде; кемгәдер сиздермәскә тырышып, бүре эзләрен тикшерә торды.* Р.Батулла

**Тикшерә төшү** Тагы да ныграк тикшерү

**Тикшереп алу** Тиз һәм җиңелчә генә тикшерү. *Ерак сәяхәткә җыенгандай, ул үзенең ашык-пошык кына киелгән өс-башын тикшереп алды.* А.Хәлим. *Урал, як-ягына каранып, тирәюньдә шымчылар күренмәвен тикшереп алды да сүзен дәвам иттерде ---.* Т.Галиуллин

**Тикшереп бару** Даими, системалы тикшерү. *Бигрәк тә соңгы елларда агрономиянең бөтен яңалыкларын укып, тикшереп бардым.* Ш.Хөсәенов. *Комбатның сүзе Божедомовның бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыккандырмы, әллә комбат үзе биргән фәрманның үтәлешен тикшереп бармагангамы, ичмаса, берәрсе чаңгы турында сүз кузгатсачы.* С.Шәрипов

**Тикшереп бетерү** Барысын да ахыргача тикшерү. *Үз колакларына үзе ышанмый иде ул: Диләрамны тиешенчә тикшереп бетермичә операциягә салуда Дәүләтшин аны – Ильясованы гаепли түгелме?* Г.Әпсәләмов. *Көн тәртибендә торган беренче, икенче мәсьәләләрне тикшереп бетергәч тә,*

*Гасыйм аудиториягә бераз тынычсыз, җитди күз карашы ташлап алды ---.* Н.Фәттах

**Тикшереп җиткерү** Ахыргача, тиешле дәрәҗәдә тикшерү. *Бу эшне тикшереп җиткерергә кирәк*

**Тикшереп йөрү** Һәр җирне тикшерү; шактый вакыттан бирле тикшерү. *Типкә би, үзенең бер-ике кешесен ияртеп, иртәдән башлап кичкә кадәр ат өстендә килеш, әледән-әле барысын күзәтеп, тикшереп йөрде.* Н.Фәттах. *Аның Вафага акча биреп куюы турында, шадраның төрмәгә эләгүен беркемгә, хатынына да сөйләгәне юк лабаса! Димәк, Наилә аның тормышын, һәр адымын капшап, тикшереп йөри дигән сүз!* А.Гыйләҗев

**Тикшереп карау** Сынау максаты белән тикшерү. *Тиз генә тирә-юньгә күз сала, куак араларын караштыра, башы әйләнеп китеп суга егылмады микән дип, көянтәсе белән басма тирәсен тикшереп карагандай итә.* Г.Галиева. *Каяле, кесәләреңне тикшереп карыйк, коралың юкмы икән?* В.Нуруллин

**Тикшереп тору** Һәрвакыт тикшерү, әледән-әле тикшерү; хәзерге моментта тикшерү. *– Сабагын белеп кайтканмы? – дип, һәр көн җентекләп тикшереп торадыр иде.* Г.Камал. *Шулай ук чәчелгән түтәлләргә җыелып барып, һаман тикшереп торырга, тикшергән нәрсәләрне тагын да язып барырга кирәк.* Һ.Такташ

**Тикшереп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тикшерү. *Шулай да куелган тәртипне бозмас өчен, исемлек буенча, «Әпсәләмов, Әминова, Биктимеров» дип, балаларны тикшереп чыкты ---.* Г.Кутуй. *Беренче тапкыр имезергә китерү белән, ул аларны чишендереп ташлады һәм бөтен җирләрен тикшереп чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**ТИКШЕРҮ** II *и.* 1) *юр.* Җинаятьнең барышын, сәбәпләрен, нәтиҗәләрен һәм гаепләләрне ачыклау эше; тәфтиш

2) *к.* **тикшеренү** II. --- *тамырга бик нык берегеп, аның белән тәмам бербөтен булып укмашкан, хәзерге тел аңында кушымча икәнлекләре сизелмәслек булган, бары тик чагыштырмалытарихи тикшерүләр юлы белән генә аерыла алган бик борынгы, җансыз кушымчалар бар.* Г.Алпаров. *Чынлап та, бер төркем тикшерүләрдән күренгәнчә, көньяк-көнчыгыш башкортлары белән чагыштырганда, төньяк-көнбатышта яшәүчеләрнең социаль-икътисади үсеш темплары югарырак булган.* Д.Исхаков

**ТИКШЕРҮЧЕ** *и. юр.* Берәр җинаять һ.б. турында мәгълүматлар җыеп, аны хөкемгә әзерләүче белгеч; тәфтишче. *Зәй --- җинаять эзе табылмады дип, «дело»ны япмакчы булгач, --- прокурорга жалу язды. Шуннан соң «дело»ны тикшерүчегә бирделәр. Ефимов фамилияле өлкән лейтенант.* Х.Камалов

**ТИЛ** *и. фар. иск.* Күңел, хәтер. *Тилемдәге телемдә.* Әйтем

**ТИЛАВӘТ** *и. гар.* Коръәнне матур тавыш белән һәм бөтен тәҗвид кагыйдәләрен саклап уку. *Өйләрдә тилавәт үзенең бөтен куәте белән хөкем сөрмәктә иде.* Г.Газиз

**ТИЛАВӘ́Т ИТҮ** *ф.* Коръәнне тавыш белән уку

**ТИЛБЕР** *с. сир.* Артык шаян; тиктормас, хәрәкәтчән. *[Зөлфирә:] Чөнки син тилбер! Тик тормыйсың бит син. Күз-колак булмасаң, әллә кайда әллә кемнәр белән әллә ниләр эшли аласың.* З.Хәким

**ТИЛГӘН** *и. зоол.* Карчыга кошлар семьялыгыннан эре гәүдәле, кәкре томшыклы, үткен тырнаклы, соры төстәге erткыч кош; кагау; *русчасы*: **коршун**. *Майның соңгы көннәре – җирнең ирткен сулап бер киерелгән, тыныч күктә тилгәннәр тирбәлгән, тал песиләрендә умарта кортлары гөжләгән беренче тыныч язның иртәсе иде.* М.Мәһдиев. *Тилгәннәр дә тавык чебешләрен, каз бәпкәләрен чыркылдатып алып китәләр бит.* А.Хәлим

**ТИЛЕ** *с.* **1.** 1) Зиһене һәм фикерләү сәләте зәгыйфь булган; дивана, акылсыз. *Үзең юләр булсаң да, сүзләрең шактый акыллы күренә. Юк, бер дә тиле кешегә охшамагансың син, тиле булып кыланасың гына!* Р.Вәлиев. *Әйтерсең лә тарихта XX съезд булмаган, Никита Хрущёв, имеш, шыр тиле, дивана, сантый булган...* А.Тимергалин

2) Җилкенчәк, җилбәзәк, ашкынучан, ярсу. *Тиленең тиңе булмас.* Мәкаль. *Җитез җилдәй аны алга әйдәүче көч – йөрәктән ургылган тиле яшьлек ярсуы, яңа борнаган мәхәббәтнең алгысынулы ашкынуы иде.* А.Вергазов

3) Уйламыйча гына эш итүчән. *Уйлаган илле кеше, ярып салган (әйтеп биргән) тиле кеше.* Мәкаль

4) Артык мавыгудан, җилкенүдән туган. *Илһам дустының әчке халәтен бик яхшы аңлый, аның күзләреннән элекке тиле дәрт белән янучы утны күпме генә эзләсә дә, таба алмый.* Ф.Садриев. *Нәүфәлен яратуы, аны үстергән бу якларга соклануы, шушы җирнең үз кешесе булырга омтылуы тартәгә тибәргә котырткан тиле теләктән мең мәртәбә көчлерәк иде.* Сөембикә

5) Ахмакларча, акылсызларча эшләнгән, әйтелгән, уйланган. *– Сәрвия оныгы Галиярның тиле сүзләреннән минем дә башка инеш кебек сай уйлар керә башлады, каһәресе, – дип сукранды ул.* М.Хуҗин. *Мәктәптә укыганда, хәтта студент елларында, әгәренки Хәбибулла абзыебыз --- баеп китеп, үләр алдыннан, туплаган малын кая куярга белмичә, варисларын эзли башласа, кызык булыр иде, кебек тиле фикерләр күңелгә килмәде түгел.* Т.Галиуллин

6) Акылга зәгыйфь кешенекедәй. *Шулай ярым саташып, тиле хәлсез күзләрен төрле якка йөрткәндә, сәкедә ике әйбер күренде...* Г.Ибраһимов. *Ул бит --- ир хатыны... Аны мин тиргәргә, оялтырга тиештер. Тик көчем җитми ---. Алай гына да түгел, шушы тиле караштан исерткеч шатлык, юаныч алам ---.* Ә.Баян

**2.** *и. мәгъ.* 1) Юләр, тинтәк, ахмак, акылга зәгыйфь кеше. *Тиле, тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерер.* Мәкаль. *Тиле тилене табар.* Мәкаль. *Соң, тиленең тиле икәне маңгаена язылган инде.* А.Гадел

2) Ачусыз шелтә яки йомшак кына сүгенү сүзе. *Бу юлы Гөлшәһидәнең «тиле» дигәннәре иң-иң зур ярату сүзе булып яңгырый иде.* Г.Әпсәләмов. *Тиле, хәзерге заманда саклык кассасына акча салалармыни!* З.Мәхмүди

3) Берәр нәрсә белән бик мавыгып киткән кеше; берәр эш-шөгыльнең фанатигы. *Бер иптәше Зыяны «музыка тилесе» дип атый.* Г.Ибраһимов

◊ **Тиле кәккүк (күке)** 1) Гадәттәге күкелдәү чорыннан элек яки шуннан соң күп вакыт үткәч күкелдәгән кәккүк; 2) Нишләгәнен үзе дә белми аптырап, йөдәп, миңгерәп, аңгыраеп йөри торган кеше. *Бөтен уй-хәсрәтләрем үз эчемдә, уртаклашыр кешем юк, булса да, бу кадәр тирән серләремне әйтә алмас идем, тик шунда тиле кәккүк кебек ялгызым миңрәүләнеп йөрим дә йөрим.* Ә.Еники. *Һәй, нәрсә әле без, тиле күкеләр сыман, чит кеше ишегалдында кычкырышабыз?* А.Гыйләҗев. **Тиленең акчасы торна булып кычкыра** Акчасын тота белмәүче, юкка-барга әрәм-шәрәм итүче кеше турында. **Тиле пуля** Сугыш кырында төзәмичә яки ялгыш атып, очраклы рәвештә кемгәдер килеп тигән пуля. *Әйтик, минага барып басу, тиле пуляга эләгү, юк-бар нәрсә эчеп агулану – әзмени шундый ахмак үлемнәр.* М.Әмир. **Тиле торна** Гәүдәсе, кыланышлары яки өс-башы җыйнаксыз кеше. *Ә мин, тиле торна, өр-яңа косынкамны өстерәп барам.* Совет әдәбияты. **Тиле ядрә** *к.* **тиле пуля**. *Тиле ядрә, кайда кунарга дип, кулыңны-билеңне сайлап кунмый.* А.Хәлим

**ТИЛЕАКБАШ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан калкансыман оешкан ак чәчәкле, каурыйсыман телгәләнгән вак яфраклы, исле күпьеллык үләнчел үсемлек; меңьяфрак; *русчасы:* **тысячелистник**

**ТИЛЕБӘРӘН** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан туры сабаклы, киң яфраклы, сары шәмәхә чәчәкле, вак кара яки сары орлыклы икееллык агулы үлән үсемлек; *русчасы:* **белена**. *Аксыргак тамырын, орлыклары коелмаган тилебәрән сабакларын, тагын исемнәрен үзе генә белгән кайры, үлән, тамырларны аралап алды.* Л.Зөлкарнәй. *Тилебәрән орлыгының агу икәнен үләнче кыз белмәде микәнни?!* Н.Гыйматдинова

◊ **Тилебәрән орлыгы ашаган** Юләр, тиле-миле, ахмак, аңгыра. *Аһ, юләр мин, тиле, аңгыра баш, тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстә, аңгыминңге, туксан тугыз, акы-чокы, Рабига сүзе белән шул никахка риза булдым бит.* Р.Батулла. *Яшәүдән туйдыңмыни? Тилебәрән орлыгы ашаган аңгыра нәмәстә!* Р.Мулланурова

**ТИЛЕБОДАЙ** *и. бот.* Башаклылар семьялыгыннан туры нечкә сабаклы, ачык яшел яки куе яшел озынча яфраклы, башаксыман чәчәкле, иген басуында үсә торган бодайга охшаш кыяклы чүп үләне; *русчасы:* **плевел**

**ТИЛЕЛӘНҮ** *ф.* Тилелек күрсәтү, акылсыз рәвештә җилкенү. *Ул кичне Сәгыйть гел аның янында гына булды, гел аның белән генә диярлек биеде, көлде, тилеләнде, каяндыр мәзәк, көлке сүзләр эзләп тапты.* Н.Фәттах. *– Нишләп юләрләнеп йөрисең? – дип дәште Фира. – Рашатның тавышы шул яктан килә, – диде Гайшә апа. – Нинди тавыш, тилеләнмә, зинһар!* Х.Камалов

**Тилеләнә бару** Торган саен көчлерәк тилеләнү. *Хамисә аның саен урамны яңгыратып көлде, үчекләде, ә Нәҗип аның саен тилеләнгәннән тилеләнә барды.* Ә.Дусайлы

**Тилеләнә башлау** Тилеләнергә тотыну

**Тилеләнеп алу** Кинәт кенә, берара тилеләнү. *Кышкы ачлыктан соң кинәт кенә яшел чирәмгә баскан сыер халкы шулай бер-ике атна тилеләнеп ала.* Г.Гыйльманов

**Тилеләнеп йөрү** Шактый вакыт тилеләнү; теләсә кайчан, теләсә кайда тилеләнү. *Ләкин иртәгәгә кадәр бик озак көтәсе бар иде. Ул сүреләп төште. Чыннан да, алай тилеләнеп йөрергә аның ни хакы бар соң?* Н.Фәттах. *Нәрсәгә сиңа җылысы беткән, чишелмәгән проблемалар белән тилеләнеп йөргән карт профессор!* Н.Кәримова

**Тилеләнеп кую** Кинәт тилеләнү

**ТИЛЕЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Тилеләр кебек, тилегә охшап; онытылып. *Ә бүген ул тилеләрчә бии, клуб алдындагы чирәмне авыр дагалы күн итеге белән таптый.* М.Мәһдиев. *Руслан минем сүзләремне ишетми иде инде, --- үзалдына тилеләрчә елмаеп, күндәм генә янәшәмнән атлады.* А.Әхмәтгалиева

**ТИЛЕЛЕК** *и.* 1) Үз акылында булмау, тиле булу хәле; акылга зәгыйфьлек, юләрлек

2) *күч.* Дуамаллык, башсызлык; уйламыйча эш итү очрагы яки гадәте. *Элгәреге үземнең әллә нинди дәрт берлә эшләгән эшләремне тилелеккә хисап кыла башладым.* Г.Исхакый. *Китсен Тотыш, китсен тизрәк! Эшкә җигелсә, тилелеген онытыр, кеше булыр.* Н.Фәттах. *Синең исемең йөз кабат язылган кәгазь белән бергә бөтен тилелекләрне, соңгы талпынышларны учка кысып, кәрзингә аттым.* Ә.Баян

3) *күч.* Ашкыну, кайнарлык һ.б.ш. аркасында булган урынсыз кыланыш. *Элеккеге ачы тойгыларга, үпкәәрнүләргә яшьлек тилелеге, яшьлек кайнарлыгы өстәлде.* Н.Фәттах. *И сабыйлык хыяллары, балачак тилелекләре!* Э.Халидов

**ТИЛЕМЗӘК** *и. бот. к.* **тилерткеч**. *Тилемзәк җигән [ашаган] – аекмас.* Мәкаль. *Тилемзәк, теләү, таргыл һәм тагын кайбер сүзләргә «сирәк» искәрмәсен куюга караганда «искергән» дип билгеләү урынлырак булыр иде, чөнки һәрбер сүз борынгы бер мәкаль белән иллюстрацияләнгән.* Ф.Сафиуллина

**ТИЛЕ-МИЛЕ** *с.* **1.** 1) Тилегә тартым, килделе-киттеле, акылга җиңел. *Киноларда, театрларда күрсәтелә торган тиле-миле, чеп-чи надан һәм дорфа председательләргә чак кына да охшамаган иде ул.* М.Хәсәнов. *Синең кебек тыйнак, акыллы егеткә чыккан тиле-миле хатын-кыз да рәткә керәчәк.* Р.Сәгъди

2) Тирәнтен уйланылмаган, мәгънәсез. *Бичәсе аның хәлен аңлый, билгеле, тиле-миле сораулар белән диңкетми, уң ягындагылар белән генә сүз алмашкалый.* Ә.Еники. *Һади, тиле-миле уйларыннан арына алмаган бер халәттә, имтихан турында түгел, --- кайда да булса эшкә керү турында баш вата башлый.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Ә минем тиле-миле пыр туза: «Чукынып кына бет, хаҗәтемә кирәгең юк!» – ди.* Ш.Камал. *Кәмит күреп, авызын ачып катып калган тиле-миле кебек, урам чатында тәк басып тора.* Т.Галиуллин

**ТИЛЕМСӘ** *с. сөйл.* **1.** 1) *к.* **тиле-миле 1.** (*1 мәгъ.*). *Булса да булыр икән үз кадерен үзе белмәгән тилемсә бәндәләр!* М.Хәсәнов. *Испан язучысы*

*Сервантесның тилемсә герое Дон Кихотка ишарә иде бу, юк артыннан куасың, дигән сүз иде.* М.Маликова

2) *к.* **тиле-миле 1.** (*2 мәгъ.*). *Ихтыяр, башына берөзлексез килеп торган тилемсә уйлардан котылырга теләп, тиз-тиз генә саубуллашты да урамга чыкты.* Р.Вәлиев. *Мин, телсез курчак шикелле, ә дияргә дә, җә дияргә дә белмичә, ниндидер тилемсә елмаю белән газиз кешемә төбәлдем.* А.Әхмәтгалиева

3) Җилбәзәк, җилкенчәк, ашкынучан. *Алты ел – тилемсә яшьлекнең ташкын тойгыларын сүрелдерә төшәргә җитәрлек вакыт иде.* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. – *Ә безнең тилемсә, – ди әти, – оралмаган олы күсәк күтәргән, дигәндәй, чабаталы башы белән сугышкан булып маташа*. Г.Бәширов. *Нишли бу тилемсә, нишли? Кызның гайрәтен үзеннән чигерер дә куяр, шул булыр.* М.Хәсәнов

**ТИЛЕРЕП** *рәв.* Әсәрләнеп, бик бирелеп, дөньясын онытып. – *Менә шул, – дип дәвам итте артист, – сандугачларның тилереп сайрауларын тыңлый-тыңлый, койма буена бардым.* Г.Әпсәләмов. *Янында чалкан яткан кешеңнең, сине өзелеп, тилереп яратуын белгән хәлдә дә, миен, зиһенен биләгән уй-хыялларын, күңел күзен ахыргача аңлый алмыйсың.* Т.Галиуллин

**ТИЛЕРТКЕЧ** *и.* **1.** 1) бот. Паслёнчалар семьялыгыннан бүрәнкәсыман эре чәчәкле, түгәрәк кара орлыклы, корыга чыдам агулы үсемлек; тилемзәк, тиле ут; *русчасы:* **дурман**

2) Тилертә торган нәрсә. *Кайдан табасы шул тилерткечне!*

**2.** *с. мәгъ.* Тилертә торган. *Ул шешәдә аның тилерткеч дарулары күп иде бит әле.* Ф.Бәйрәмова. *Аракысы аракы булса ярар иде әле – адәм тилерткеч нәрсә.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ТИЛЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тилерү**. *Акыллы кешеләрне дару биреп тилертәләр.* Р.Батулла. *Ире Шәгаетов, хатынымны Сәрвия тилертте, дип, судка биргән.* М.Хуҗин

2) *күч.* Ярсыту, җилкендерү яки аптырашка калдыру. *Шашкан күңеле тәмам тилертте аны. Һәм Иргали тәвәккәлләде: йөрәкләнеп китеп, бөтен ихтыярын бергә туплады да җиңелчә генә ишек келәсенә кагылды.* М.Хәсәнов. *Яшьлегең тилертә сине, кияү, яшьлегең!* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Алдау, алдалау. *Сезнең дин дип йөртә торган нәмәрсәгез – кара халыкны тилертеп йөртә торган бер агу гына.* С.Җәлал

**Тилертә башлау** Тилертергә тотыну. *Бу урыс соңгы елларда Зыя белән дә якыннан таныш булганга, аның хәятын белә, зарларын аңлый --- иде. Шуны игътибарга алып, хәзрәтне җиңәрлек яктан тилертә башлады: – Бу ни эш, мулла? Син харап икәнсең!* Г.Ибраһимов

**Тилертә язу** Чак кына тилертмәү. *Тотыш алыпның суарларны җиңеп кайтуы Корыч-Тимерне чын-чынлап тилертә язды.* Н.Фәттах

**Тилертеп алу** Берара, бераз гына тилертү. *Йөрәк күзәнәкләренә әллә нинди ярсыткыч, җилкендергеч, шаштыргыч моң салып, сине бераз тилертеп ала ---.* С.Поварисов. *Нияз кайчан кайта бит әле? Кайткач аны алырмы? Карт кызга әйләнеп куймасмы? Әнә шундый икеләнүләр аны бераз тилертеп алды.* Ә.Моталлапов

**Тилертеп бетерү** Бөтенләй тилертү, бик нык тилертү. *Бөтен шәһәрнең танылган экстрасенсы, күрәзәчесе, күпме халыкны сөйдерткеч-биздерткеч агулары белән тилертеп бетергән данлыклы керәшен хатыны бер ир-атны үзенә карату өчен көче җитмәгәнлеген сизде.* Ф.Бәйрәмова

**Тилертеп җибәрү** Кинәт кенә тилертү. «*Бала» сүзе Исламны тилертеп җибәрде.* Н.Фәттах. *Беренче --- мәртәбә бераз шаяру катыш булса да «сөям» сүзен ишетү егетнең шашкын күңелен бөтенләй тилертеп җибәрде.* Ф.Яруллин

**ТИЛЕРҮ** *ф.* 1) Тилегә әверелү, акылдан шашу, юләрләнү. *Фатиха абыстай тилергән иде.* А.Хәлим. *Мин кайгыдан тилерер хәлдә аны көткәндә, Алия күрше шәһәрдә ниндидер егеттә яшәгән!* Идел

2) Җилкенеп, әсәрләнеп, уйламыйча нәрсә дә булса эшләү, җиңел акыллылык күрсәтү. *Утыз яшькә җитеп, картаеп беткәчтен гыйшык тотып тилереп йөр ---, имеш.* М.Фәйзи. *Бер тилереп калыйк яшь чакта.* Т.Миңнуллин

3) Котырыну, ярсыну, шашыну. *Җил котыра, тилерә, шаша…* Н.Гаетбай. *Борын хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр, ул китү белән, берәүнең тәгъбиренчә, бәйләүдән ычкынган этләр кебек, дулый, тилерә, башларына килгән һәрбер эшләрне кыйла башладылар.* Г.Ибраһимов

4) Тиләләнү, акылсызлык эшләү, исәрләнү. *Без тилереп йөргәндә, бер генә кеше тыныч: ул Айнурия иде. «Әти хәзер керә», – диде чыршы бизәү белән мавыккан кызчык.* Н.Гыйматдинова

**Тилерә бару** Торган саен тилерүгә арту. *Хатын да шундый туры килде. «Сез – яхшы кешеләр», – дигән саен тилерә бара: чәй әзерли, аш чыгара, сыйлый башлый.* Һ.Такташ. *Мин аңардан читләшергә тырышкан саен, аның дәрте котыра, тилерә барды.* Т.Галиуллин

**Тилерә башлау** Тилерү билгеләре барлыкка килү. *Икенче көнемдә үк үземә тилерә башлаган алты яшьлек бер ир баланы китерделәр.* Г.Кутуй. *Этне озак бәйдә тотсаң, тилерә башлый.* Н.Фәттах

**Тилерә язу** Тилерү дәрәҗәсенә җитү. *Шатлыктан тилерә яздык: еладык та, көлдек тә!* Ә.Еники. – *Карагыз әле! – диде бу хәлдән тилерә язган участковый. – Сез миңа нинди спектакль куясыз, ә?* Х.Ибраһим

**Тилереп алу** Беркадәр, аз гына вакыт тилерү. *Күрәсең, бер болганмый су да тынмый, дигән шикелле, җан тынычланыр өчен дә башта йөрәкнең бер тилереп алуы кирәктер инде.* Г.Әпсәләмов. *Эчкәч, биш минутка тилереп алам.* Ш.Галиев

**Тилереп бетү** Тәмам, бөтенләй тилерү. *Николай Максимович, ак түшәмгә карап ята-ята тилереп беттем, дип әйтә идегез, чын икән.* Г.Әпсәләмов. *Тилереп беттегез инде барыгыз да.* Н.Фәттах

**Тилереп йөрү** Шактый вакыт тилерү; теләсә кайчан, теләсә кайда тилерү. *Икенче болай кеше көлдереп,*

*тилереп йөрүеңне ишетәсе булмыйм.* Ә.Еники. --- *рабфакта укыганда, ул чын-чынлап, шагыйрь булам, дип тилереп йөрде.* Н.Фәттах

**Тилереп калу** Нинди дә булса сәбәптән соң тилерү. *Кызы югалган хатын да тилереп калган кебек: бер сүз эндәшми, хәтта елый да алмый.* Х.Камалов

**Тилереп китү** Кинәттән тилерү. --- *нәрсә сөйләшкәнебезне хәтерләмим, тик шул чакта мин, ничектер тилереп китеп, калын гына киенгән кодачаны кочаклап үбәргә тырышып карадым.* Ә.Еники. *Н. авылы тегеләй дә юк-барга бик тиз ышанучан булганга, хәбәрләр якын-тирә авыллардан үрмәли башлагач, халык бөтенләй тилереп китте.* А.Гыйләҗев

**Тилереп яту** *сөйл.* Шактый вакыт тилерү. *Әгәр анда Камилә ул төймәләре белән бөтенләй ычкынып, тилереп ятса?* Ф.Бәйрәмова. *Безнең аулак өйдә дөньябызны онытып тилереп ятулар әллә ни озакка бармады: әнине, терелтә алмагач, хастаханәдән кире өйгә җибәрделәр.* Ш.Алпар

**ТИЛЕСУГАН** *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан яшел суган өчен үстерелә торган күпьеллык суганның бер төре; батун. *Тилесуган сабакка уңар.* Мәкаль

**ТИЛЕТОРМА** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан сабаклары тармаклы, сары чәчәкле, баллы үсемлек, чүп үләне; *русчасы*: **редька полевая, редька дикая**

**ТИЛЕУТ** *и. бот. к.* **тилерткеч**

**ТИЛЕ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **тилебәрән**. *Әллә сез тиле үләне ашадыгызмы?* Т.Госман

**ТИЛЕХАНӘ** *и.* Акылын жуйганнарны дәвалау йорты. *Батыргали агай --- эчә-эчә тәмам тилереп, тилеханәгә тотып ябылгач, Бакудан туган җире Казанга җибәргәннәр иде.* Ш.Мөхәммәдев

**ТИЛЛИ́Н-ТИЛЛИН** *иярт.* Кыңгырау тавышын белдерә. *Бик ерактан тиллин-тиллин итеп Кытыкладырды төнне кыңгырау.* Х.Туфан

**ТИЛМЕРТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тилмерү**. *Эссе кояш нурлары бер йотым суга тилмертә.* С.Поварисов. *Ник тилмертә икән ул Фәһимәне, ник очраштырмый икән?!* Н.Гыйматдинова

**Тилмертә башлау** Тилмертергә тотыну. *Каян күңелемә килгәндер, туган көнгә дусларны чакырыйк дип, әнине тилмертә башладым.* Э.Җәләлиева

**Тилмертеп бетерү** Нык тилмертү. *Синнән башка беркемем дә юк минем. Сәбиләне дә тилмертеп бетердем. Янәшәмдә ул да булмаса, күптән чыгырдан чыгар идем инде.* Р.Вәлиев. *Айдарның әти-әнисе, улларының ничек укуы хакында кызыксынып, «төркем старостасы»н тилмертеп бетерә.* Э.Фатыйхова

**Тилмертеп килү** Күптәннән тилмертү. *Ел башыннан бирле --- тереклекне бер тамчы суга тилмертеп килеп, көзгә чыккач, табигать илләрне күктән иңгән туктаусыз яңгырлары белән интектерергә тотынды.* А.Галимов

**Тилмертеп тору** Хәзерге моментта тилмертү; даими, гел тилмертү. *Икедән соң гына бушый бүлмә, дип тилмертеп торсалар нишләрбез, дип борчылган идек.* Сөембикә

**ТИЛМЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса бик мохтаҗ булу, мохтаҗлык кичерү; газаплану. *Яфракларның бер ягы гел көн сөя, икенчесе яктылыкка тилмерә.* К.Тинчурин. *Миңа уникe яшь, ачлыктан, йокы җитмәүдән мин бик тилмерәм, йончыйм.* М.Мәһдиев

2) Зарыгу, интегү, газап чигү, йөдәү, җәфалану. *Аэродромга төшкәч, синоптиклар кисәтеп куйдылар: – Давыл булырга тора, көтәргә кирәк. Моңа каршы Мансур бары тик: – Анда авыру тилмерә, – диде.* Г.Әпсәләмов. *Ул Фаягөлнең, Шәрифтән хат көтеп, ут эчендә янганын бик яхшы аңлый, үзе дә, көн туса, иреннән хәбәр көтеп тилмерә.* А.Әхмәтгалиева

3) Ялыну, ялвару. *Кайсының эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары, балаларыбыз авыл җирендә авырып-нитеп китә күрмәсен, дип курккалар да булса кирәк, кыскасы, бер атна торгач та, карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, --- китеп тә баралар.* Ә.Еники. *Шул каргыштан соң да ике егет озак ялвардылар гафу сорап, ярдәм көтеп байтак тилмерделәр, тик бәгыре каткан Фәйзария алар уфтанганга гамьсез калды.* Р.Батулла

**Тилмерә башлау** Тилмерергә тотыну. *Гөлтуташ Тимерҗанны дүрт күз белән көтеп тилмерә башлады.* В.Имамов. *Яшерен-батырын түгел, соңгы елларда театрда җыр-биюле, оркестр белән куелган спектакльләрне карарга тилмерә башладык.* Ватаным Татарстан

**Тилмереп бетү** Тәмам, бик нык тилмерү. *Тик Тиенне көтә-көтә тилмереп беткән Аю кышкы йокыга талган икән.* Әкият. *Аларның кайтуын көтә-көтә тилмереп беткән Гөлнур, бу хәбәрне ишеткәч, өлкән врач янына чапты, Фоатны эзләргә берничә сугышчы белән үзен җибәрүне үтенә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Тилмереп йөрү** Озак вакытлар дәвамында тилмерү. *Төн буена кара урман эчендә тилмереп йөргәннән соң, миңа монысы да бик зур бәхет сыман тоела иде.* М.Вәлиев

**Тилмереп тору** Хәзерге моментта тилмерү; даими, гел тилмерү. *Төрмәнең бу як капкасы төбендә дә, нәкъ кичәге кебек, туганнары, таныш-белешләре янына килүчеләр тилмереп тора.* Р.Кәрами. *Чөнки менә хәзер, аның белән бергә биш ел укыйсы егерме дүрт группадашы алдында, шуның өстенә тегеләр бер кабым закускага тилмереп торганда, әлеге казылыкны чыгарсаң да була иде!* В.Нуруллин

**Тилмереп яту** *сөйл. к.* **тилмереп тору**. *Шуңа күрә хәзер оныгыбызны күрергә тилмереп ятабыз бит инде…* М.Вәлиев. *Хәзер кулларыңа богау салып, КПЗга алып китеп ябабыз да, судка кадәр якын туганнарыңны да күрергә тилмереп ятарсың.* Ш.Алпар

**ТИЛПЕНҮ** *ф. сир.* 1) Җилпенү, талпыну, очып китәргә омтылу. *Бу бала сыерчык булып очып киткәч, Зөһрә бер тилпенә, ике тилпенә, өч тилпенә дә күгәрченкәй кошка әверелә.* Әкият. *Әмма учка сыярдай гына җан кисәге шул мизгелдә үк әллә ничек кенә янә калкынды, бер тын түбәндә эленеп торды, аннары җитез-җитез тилпенеп, янә югарыга үрли башлады һәм күз ачып йомган арада диярлек һава зәңгәрлегендә юк та булды.* Э.Касыймов

2) Нәрсә дә булса эшләргә тырышу, берәр хәрәкәт ясау. *Хәтта ул, нидер әйтмәкче булып, болар ягына килергә дә тилпенде, Фәритнең күзләре кепканың козырёгы астында теге вакыттагы төсле елтырап киттеләр.* Г.Бәширов

3) *куч.* Тибрәнү, җиңелчә селкенү. *Шәм уты тилпенү*

4) *куч.* Җилкенү, ашкыну. *Бу тавыш белән бергә моңлык бөтен тамырларга тарала. Күңел тилпенә, җан ашкына, куркына да.* Гали Рәхим

**Тилпенә башлау** Тилпенергә тотыну. *Ситсы пәрдәнең эре бизәкләрендә шәүләсен уйнатып, учак астында ялкын да тилпенә башлады.* М.Хәсәнов

**Тилпенеп алу** Бераз, кыска вакыт эчендә тилпенү. *Хәбибнең хатыны шул айда гына тагын бер тилпенеп алды ---.* М.Мәһдиев

**Тилпенеп җибәрү** Кинәт тилпенү. *Тычкан моның каршысына килеп чыгып тилпенеп җибәрә дә кеше сурәтенә керә ---.* Әкият

**Тилпенеп карау** Тикшерү-белү максаты белән тилпенү. *Көрәш озакка сузылды. Егетләрнең әле берсе тилпенеп карый, әле икенчесе йолкып алмакчы була.* Г.Бәширов. *Узган елгы гадәт буенча мулла хатыны дин сабагы укытмакчы булып тилпенеп караган иде, барып чыкмады.* Г.Бакиров

**Тилпенеп кую** Кинәт, бер тапкыр тилпенү. *Байтимер кинәт кенә башына нидер килеп тилпенеп куйды.* Г.Бәширов. *– Алар аңа чит-ят кеше түгел бит, үз абыйлары! – дигән бер өмет кенә тилпенеп куйгалый иде күңелдә.* Н.Хайтов

**Тилпенеп тору** Озак, даими рәвештә бертуктаусыз тилпенү; хәзерге моментта тилпенү. *Салкын сарай алдында Тилпенеп тора бер күркә ---.* К.Насыйри

**ТИЛХАТ** *и. фар. иск.* Нәрсә дә булса алуны раслап язылган кәгазь; *русчасы:* **расписка**. *Тилхат биреп акча алу*

**ТИЛЧӘ** *и.* 1) *вет.* Партояклы малларда интоксикация, бизгәк тоту, авыз һәм борын куышлыгының лайлалы тышчасы ялкынсыну, тиренең йонсыз өлешләрендә үзенчәлекле куыкчыклар (афталар) һәм җәрәхәтләр барлыкка килү белән үтә торган йогышлы авыру. *Тилчә белән чирләгән терлекләр инфекциянең чыганагы булып тора, алар вирусны әйләнә-тирәгә, нигездә, сөт, селәгәй, бәвел һәм тизәк аша бүлеп чыгара.* Шәһри Казан

2) Гадәттә йогышлы авыру вакытында чыга торган шеш, төер. *– Но, алма агачыннан ерак төшми, дигәнне дә онытырга ярамый, нәсел – нәсәпкә, тилчә – тамырга, ди минем әби, – диде, йомгак ясагандай катгый итеп Лениза.* М.Маликова. *Я, я килен, ир-атка тел озайтма, тилчә чыгар.* Г.Каюмов

◊ **Тилчә тел** Чиктән тыш усал телле кешегә карата әйтелә. *Аның [Гайнинең] тилчә теленә адәм түгел иблис тә чыдамас.* Ф.Бурнаш. **Тилчә телле** Зәһәр, чәнчүле сүзләр кулланучы. *Бәрәңге чүпләүче хатыннар арасыннан тилчә телле Зөмәрә, күрмәмешкә салынып-мы, сөйләнеп китте: – Я, кем әйтер бу малайны аныкы түгел дип?* Н.Хәсәнов. *Кыз үзенең каршысында тилчә телле халык шамакае басып торганын һаман аңламый кебек.* Р.Батулла

**ТИЛЧӘЛӘНҮ** *ф.* Шеш, төер чыгу. *Мөбарәктәге тел байлыгы хәйран мул иде ---. Югыйсә бу, таш астыннан чыккандай, тәвәккәл, үткен күрше егетенең оста теле тик бүген генә тилчәләнмәгәндер инде!..* М.Шаһиморданов

**Тилчәләнеп бетү** Бик нык тилчәләнү

**ТИЛЧӘЛЕ** *с.* 1) Тилчә белән зарарланган. *Бозаулар кырылганга берәү дә җавап бирмәде. Тилчәле булганнар дип, мал докторы Зиканнан язу яздырып акт төзеделәр дә, эшең бетте, кодагый!* Р.Батулла

2) Тилчә чыгу белән үзенчәлекле. *Ул* **---** *тилчәле авырулардан да җирәнми иде.* Г.Тукай

**ТИ́ЛЬДА** *и. исп.* Дулкынсыман сызык (~) формасындагы типография тамгасы

**ТИ́МӘГӘН** *с.* 1) Нинди дә булса кораллар турында сүз барганда: шул кораллар белән эшкәртелмәгән булуны аңлата. *Мондый вакытларда кул һәм пычкы тимәгән кара урман буйлап баруы аеруча рәхәт, һава саф, җиңел, әллә нинди хуш исләр аңкый.* Г.Әпсәләмов. *--- кап-кара сакал-мыегына күптән пәке тимәгән, сәләмә генә киемле, чандыр гына гәүдәле бер кеше тегеңә якынрак килде дә куркып кына: – Мин ием дисәтник, Гата туган, – диде.* В.Нуруллин

2) Гомумән файдаланылмаган, эшкәртелмәгән. *Күптән инде түбәсе убылып төшкән, өстенә алабута, әрем үскән балчык-тирес хәрабәләргә басып, кайсы гына якка күз салсаң да, беркайчан да адәм кулы тимәгән карт дала сузылып ята.* Н.Фәттах. *Коридорда торган, күптән кул тимәгән көзгене ялт иттерде.* Ф.Яруллин

**ТИМГЕЛ** *и.* **1.** Тап (йөздә, тәндә, киемдә һ.б.да). *Тик бүген тәнендә үзгәрешләр күренә. Ясмык зурлыгындагы кызыл тимгелләр калкып чыккан.* Н.Фәттах. *Ул чәпчемәде, сабыр гына тыңлап торды. Бөрчек-бөрчек булып, битенә кызыл тимгелләр чыкты.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый таплары булган, таплы. *Аяз күңелем күгенә бүген төшкән бар күләгәләрнең дә сәбәпчесе --- шул тимгел күзле хатындыр кебек тоелды.* Р.Төхфәтуллин

2) Ат төсләрен белдергәндә: төп төстә куерак таплары булган. *Аты яхшы – тимгел күк. Ялы – көлтә төсле, утырып кына тора.* Ф.Хөсни. *Тимгел кара айгырына атланып, очты гына Шәкүр Заһирәсе янына.* Яңарыш

**ТИМГЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәнеңдер өстендә тимгелләр барлыкка килү; тимгеллегә әверелү, тимгелләр белән каплану. *Аның нәрсә әйткәнен дә аңлавы кыен иде, шуңа ул тагы да уңайсызлана, кая керергә белми, бөрешә. Ахырда тәмам битләре тимгелләнеп, ул аңарга шушы сәгатьне куенынан чыгарып бирде.* Х.Камалов. *Бите-муены тимгелләнеп кызарган Сәетҗан абый: «Әрәм булып калмасын, утынга ярый ул», – дип сөйләнә-сөйләнә, кадаксуыргыч белән эт оясының такталарын кубарып маташа.* М.Маликова

2) Тимгелле булып күренү. *Еллар, пароход койрыгы янында тимгелләнгән дулкыннар төсле кайнап, артка чумдылар.* К.Нәҗми. *Авыл уртасындагы киң мәйданда мәктәп, клуб һәм колхоз идарәсе йортларының калай түбәләре, зур-зур тәрәзәләре тимгелләнеп ялтырыйлар.* Г.Әпсәләмов

**Тимгелләнә бару** Акрынлап тимгелләнү. *Җыелышта сөйләүчеләр гаепләрен ачкан саен, рәиснең бите тимгелләнә барды.* Яңарыш

**Тимгелләнә башлау** Тимгелләнергә тотыну. *Ачудан хуҗабызның йөзе тимгелләнә башлады*

**Тимгелләнеп бетү** Тулысынча, бик нык тимгелләнү. *Бер хатын бөрешеп, тимгелләнеп беткән тавык ите сата.* Ф.Баттал

**Тимгелләнеп китү** Кинәт, капыл гына тимгелләнү. *Каюмның яңаклары тимгелләнеп китте.* Ш.Камал. *Котылгысыз үлемнең артык якынлыгын тоюдан кинәт тимгелләнеп киткән йөзен иптәшләренә борып: «Прощайте, братцы!» – дип пышылдады.* Р.Габделхакова

**Тимгелләнеп тору** Тимгелләнгән хәлдә булу. *Офыкка кадәр җәелеп киткән диңгез өсте тимгелләнеп тора.* Г.Әпсәләмов

**Тимгелләнеп чыгу** Тимгелле хәлгә килү. *Әнә ул, карашын читкә төбәп утыра, яңагы тимгелләнеп чыккан ---.* М.Маликова. *Нота алмыйча җырлаган солистларны моңарчы да пыр туздыргалады ул анысы. Әмма болай кабару, болай бүртенү – чырае тимгелләнеп чыкты хәтта! Юк, булмады.* Р.Мөхәммәтша

**ТИМГЕЛЛЕ** *с.* Тимгеле булган, тимгелләр төшкән, таплы-таплы. *Икенче язга биябез нәкъ атасы төсле чем кара яллы, борча-борча тимгелле колын бүләк итте.* А.Хәсәнов. *Зәңгәр тимгелле күлмәк итәкләре дулкыннардай тибрәтеп, аның үзен, су кошыдай йөздереп, кызның кочагына алып керер сыман.* Н.Хәсәнов

**ТИМГЕЛЛЕЛЕК** *и.* 1) Тимгелле булу

2) Үсемлекнең яфраклары тимгелләнү белән характерланган авыру. *Бу каен җиләгенең кимчелеге аның авырулар һәм корткычлар – соры черек, ак тимгеллелек, талпан һәм корткыч коңгыз белән зарарлануында.* Татарстан яшьләре

**ТИМГЕЛЛЕ́ ТИФ** *и. к.* **тиф**. *Тоткыннар арасында тимгелле тиф, дизентерия кебек йогышлы авырулар башланды.* Г.Әпсәләмов

**ТИМГЕ́Л-ТИМГЕЛ** *с.* Тимгелләр белән капланган. *Тәннәре тимгел-тимгел булып яргаланса да, нык чабындылар, ләззәт таптылар.* З.Зәйнуллин. *Фәлиновның аксыл чырае тимгел-тимгел кызыл таплар белән чуарланган иде.* Н.Гыйматдинова

**ТИМЕР** *и.* **1.** 1) *хим.* Көмешсыман ялтыравык ак төстәге, дымлы тирәлектә тутыга торган каты авыр металл; химик элемент (углерод белән кушылгач, корыч яки чуен барлыкка китерә). *Алтай тауларында яшәгән бу кавем, --- тимер ятмаларына тап булгач, чуен һәм корыч кою, алардан көнкүреш кирәк-ярагы, җир эшкәртү һәм сугыш кораллары әзерләүне ныклап башлый.* И.Хуҗин. *Уйгурстан җирләре нефтькә бай, күмер шахталары да җитәрлек, ә таулы җирләрдә тимер рудалары, төсле металл һәм гранит чыгаралар.* Р.Ибраһимов

2) Шул металлның бер кисәге. *Эшне, тимерне сагынган кулларым хезмәт рәхәтенә тарыган кебек булды.* Х.Туфан. *Тимерне кып-кызыл булганчы кыздырып, шул бетчәне яндырдылар.* А.Алиш

3) Корал-җайланмаларның шул металлдан ясалган өлеше, детале. *--- казакъ кызы тезгенне бушайтып җибәрде дә өзәңге тимере белән атның корсагына җиңелчә генә төртеп алды.* Н.Фәттах. *Мин уянмасам, син сука тимере астында беткән идең инде.* М.Мәһдиев

4) Теләсә нинди металл. *Элекке тимерлек урынына шулай йорт салып утырган да үзе яңа тимерлекнең баш остасы булып киткән, анда теләсә нинди тимер кисәген балавыздай эретәләр ---.* М.Рафиков. *Нәбиулла --- автоген белән дә, электр белән дә теләсә нинди тимерне бер-берсенә мәңге куплаunion итеп ябыштыра.* М.Хәмитов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул металлдан эшләнгән, шул металлдан торган. *Урман алдындагы үрне менгәч, такта заводының тимер морҗасы күренде.* А.Алиш. *Күрәмсең, килеп җитүләре булгандыр, башта хәрбиләрчә өзек-өзек сөйләшкән тавышлар ишетелә, шалтыр-шолтыр тимер капка ачыла ---.* А.Тимергалин

2) Теләсә нинди металлдан гыйбарәт, шуннан ясалган. *Алъяпкыч кесәсендә бер, ике, өч тиенлек тимер акчалар шактый җыелды.* А.Фәлах

3) *күч.* Бик көчле, таза; каты мускуллы. *Гатауллинның күзе нигәдер түргә – кадими киемле, елгыр күзле, тимер бәдәнле, җирән сакаллы кешегә төште.* Ф.Яхин. *Караңгы үткәннәре аркасындамы, чакматаш кебек ныклы, тимер куллы, кылыч кебек үткер зиһенле иде ул.* Х.Мөдәррисова

4) *күч.* Көчен, гайрәтен белдереп торган. *Кызыл Армиянең тимер адымнар белән якынлашып килүен сизгән инглиз илбасарлары талап җыйган малларының кайберләрен диңгезгә ташлап --- качканлыкларын сөйләде ул.* Х.Туфан

5) *күч.* Рухи нык, көчле, гайрәтле, какшамас. *Бухенвальдтагы чамасыз авыр тормыш, көн саен мыскыл итүләр, кыйнаулар бу тимер кешенең дә нервларын какшатып өлгергән иде.* Г.Әпсәләмов. *Сез – тимер ихтыярга ия булган оптимист зат. Әнә шул нәрсә Сезгә яшәү көче бирә. Киләчәктә дә көчле рухлы булыгыз!* Ф.Яруллин

6) *күч.* Эзлекле; тайпылышсыз, чигенүсез. *Армиядә, бигрәк тә сугыш вакытында, илең батып барганда, тимер тәртип иң югары дәрәҗәдә нык булырга тиеш.* С.Поварисов. *Производствоны --- туктатмас өчен, --- директор яки баш инженер бүлмәсендә көн саен планёркага җыелалар – цехлар, бүлекләрнең иң җаваплы урыннарында торучы тимер холыклы кешеләр.* Ә.Баян

7) *күч.* Югары сугышчанлык өчен, төрле чорда төрле берләшмәләргә бирелгән рәсми булмаган (атама). *1923 елда Казанда хәрби мәктәпне тәмамлаганнан соң, 24 нче Самара һәм Сембер тимер дивизиясенә рота командиры итеп җибәрелә.* Р.Һидиятуллин. *Мәскәүдән зур булмаган матрослар отряды китерттек, һәм --- Болак арты республикасы --- үзенең тимер батальоннары белән безгә сугышсыз бирелде.* Р.Вәли

◊ **Тимер кебек** Бик көчле, бик таза. *Сез артык көчле, тимер кебек. Ә андый хатын-кызлар ир-ат белән яши алмыйлар.* Ф.Садриев. *Аны тимер кебек нык куллар эләктереп алып, хәнҗәрен җиргә төшерергә мәҗбүр итте.* Р.Сәгъди. **Тимер кул** Рәхимсез хакимият. **Тимер куллы** Көчле рухлы,

ның ихтыярлы. *Дзержинский кебек кеше бул! Юк икән, аяк астында чуалып, сару кайнатып йөрмә. Үткен күзле, тимер куллы, сизгер колаклы булсаң да таманга киләчәк.* Т.Әйди. *Караңгы үткәннәре аркасындамы, чакматаш кебек ныклы, тимер куллы, кылыч кебек үткер зиһенле иде ул.* Х.Мөдәррисова. **Тимерне кызуында сугу** Эшне уңайлы вакытта, үз вакытында эшләп калу, кызу тоту, форсатны кулдан җибәрмәү. *Ильяс – тимерне кызуында сугып өйрәнгән егет, тәнәфес игълан ителеп, бию көе яңгырый башлауга, кыюлык өчен тамагын кырды һәм кыз янына юнәлде.* Н.Әхмәдиев. **Тимер талкы** Бик каты җәза; җәза булып кабул ителә торган вакыйга. *Күпнең сүзе – тимер талкы.* Мәкаль. **Тимер тарак** *к.* **тимер талкы**

**ТИМЕРАЯК** *и.* Бозда шуар өчен, аяк киеменә беркетелгән тар металл табан; шундый табанлы аяк киеме. *Ул егылуга, Вилдан җил кебек очып килеп җитә, тимераяклары астыннан боз кыйпылчыклары чәчрәтеп, кырт борыла, Мәрьямнең култык асларыннан күтәреп аягына бастыра да тагын шуып китә.* М.Маликова

**ТИМЕ́Р-БЕТОН** *и.* **1.** Арматура белән ныгытылган бетоннан гыйбарәт төзү материалы. *Арматурщиклар бармак юанлыгы тимерчыбыклардан, ерткычларга читлекләр әзерләгәндәй, тимер-бетон өчен челтәрле рәшәткәләр үрәләр.* А.Алиш

**2.** *с. мәгъ.* Шундый материалдан эшләнгән. *Хәзер таш юллар кырыена тимер-бетон конструкцияләрдән ышыклану, автобус көтү корылмалары бастырып куялар ---.* М.Мәһдиев. *Җимерелгән комплекс бинасы янына җиткәндә, проектлаштыру оешмасыннан килгән озын буйлы яшь кенә егет, уртага ишелеп төшкән тимер-бетон плитәләрне --- рулет тасмасы белән үлчәп йөри иде.* А.Вергазов

**ТИМЕРКАЗЫ́К ЙОЛДЫЗЫ** *и. астр.* Юнәлешен тәүлек дәвамында үзгәртмәгән һәм төньяк юнәлешенә туры килгән, шуның өчен ориентир буларак файдаланылган Акбүзат (Кече Җидегән) йолдызлыгының иң якты йолдызы; Котып йолдызы; *русчасы*: **Полярная звезда**. *Җидегән йолдыз җиде әйләнә – Тимерказык урынында.* Әйтем. *Ул да Тимерказык йолдызы кебек ялгыз, син дә.* Г.Әпсәләмов

**ТИМЕРКҮК** *с.* Кара көлсу төстәге (ат тур.). *Нинди генә атлар килмәгән бирегә? Кыңгыраулы, буяулы-сырлы дугага җигелгәннәре, әллә нинди ике көпчәкле тар арба такканнары, ялларына төрле-төрле тасма кушып үргәннәре. Тимеркүк, җирән, соры, кара, туры, ак атлар.* В.Имамов

**ТИМЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тимерләү**. --- *аулак бүлмәнең ишеге имән тактадан, эчтән тимерләнгән ---.* А.Гыйләҗев. *Ул мине почмакта торган тимерләнгән бик зур сандык янына алып килде.* С.Юзеев

2) *күч.* Тимер кебек кату; тимергә охшап китү, хәрәкәтсезләнү. *Батырханның --- йөзе тимерләнә, күзләренә ачу чыга.* Г.Ибраһимов. *Буыннар да инде тимерләнде, Илһам көтеп чүпчар өемендә...* Ф.Гыйззәтуллина

3) *күч.* Тимер кебек ныгу. *Тимерләнгән тамырлары Җир-ананың тирән йөрәгенә киткән мәһабәт-гаярь имәнне мең адәми зат этеп аудара алмаган кебек, Гыйрфан мулланың көчле, иман мантыйгы белән әйтелгән сүзләрен бөтен бер җәмәгатьчелек егып сала алмый.* С.Поварисов

**Тимерләнә башлау** Тимерләнү билгеләре сизелү. *– Нәрсә тагы мөгез чыгарасың? – диде, тимерләнә башлаган тавыш белән. – Карап торам, син, Зәйналов, куак артына посу ягын гына карыйсың.* Ф.Садриев

**Тимерләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам тимерләнү

**ТИМЕРЛӘ́Ү** *ф.* Тимер деталь кую, тимер беркетү, тимер белән каплау. *Аскы урамны ярып, баядан бирле берәү тимер чүки, әллә бу араларда худка киткән кул арбасына кыршау суга, әллә күчәр тимерли, чакы-чокы ямьсез тавышы колакны яра.* А.Гыйләҗев

**Тимерләп бетерү** Тулысынча, бөтен җирен тимерләү. *Аларның [Рияннарның] кат-кат тимерләп бетергән --- такта сандыклары бар иде.* Ш.Маннур

**Тимерләп кую** Алдан яки тиз арада тимерләү. *Почта ящигы белән беррәттән коридорда тора торган электр счётчигын да тимерләп куйды.* Ф.Яруллин

**Тимерләп тору** Даими, һәрвакыт тимерләү; әле, сөйләп торганда тимерләү. *Тимерләп тормасаң, атның тоягы асфальтта бер елга да түзми ул.* Ч.Мусин

**Тимерли башлау** Тимерләргә тотыну

**ТИМЕРЛЕ** *с.* 1) Тимер деталь куелган, тимерләнгән. *Ни әйтергә белмәгәч, Нина Ахуновна җиз тимерле кара ридикюленнән факсимилесын алды да өстәлдә яткан кәгазьгә баскалап, Диндаровага күрсәтте.* Х.Камалов. *– Сигез ел инженер булып эшләгән кеше мин! – дип, аңына килә алмый торган Морат кулыннан эскизны тартып алды да, тимерле үкчәләрен шыкылдатып, мастерскойдан чыгып та китте.* М.Маликова

2) Тимер белән ныгытылган яки тимердән эшләнгән. *Малай --- каршыдагы бер зур чемоданның тимерле тоткасын шалтыратырга тотынды.* Н.Фәттах. *Ул почмакта тимерле яшел сандык, аның өстендә күпертеп утырткан ястык.* М.Мәһдиев

**ТИМЕРЛЕК** *и.* Тимерче алачыгы; тимердән төрле кирәк-ярак ясау һәм тимер әйберләрне төзәтү остаханәсе. *Аннан соң колхозда тимерлек ачу турында күп сөйләштеләр.* Ә.Еники. *Ат сарайлары артында тимерлекләр, ияр ясау остаханәләре, каеш эшкәртү өчен, зур чаннарны җиргә утыртып эшләнгән алачыклар --- тезелеп киткәннәр.* З.Зәйнуллин

**ТИМЕРСЕЗ** *с.* Тимерләнмәгән, тимере булмаган, тимер деталь куелмаган. *Хамисның машинасы юлдан тимерсез чана төсле салулый-салулый бара.* Сөембикә

**ТИМЕРТАШ** *и.* Тимер рудасы. *Кызыл тимерташларның Кривой Рогтагы ятымнары – СССРда иң зур ятымнарның берсе.* Химия

**ТИМЕ́Р-ТОМЫР** *җый. и.* 1) Тимердән һәм башка металлардан торган ватык-сынык яки кирәксез нәрсәләр, металлолом. *Кайсы ватык, кайсы гамәлдән чыккан, кирәксә-кирәкмәсә дә анда-санда аунап яткан тимер-томырларның чамасы юк.* Н.Хәсәнов. *Яуширмә авылының капка төпләрендә-*

*ге тимер-томырдан, чүп-чардан күзләр камаша, кая карама – таушалган, туз-ган әйберләр аунап ята.* Г.Гарифуллина

2) Металлдан эшләнгән һәртөрле әйберләр, кирәк-ярак. *Бер кесәсеннән шыбырдап борчак коелды, әллә нинди тимер-томырлар, шөрепләр чәчелеп китте.* Г.Сабитов. *Карт нигәдер йоклый алмады. Тәүге таң нуры тәрәзә пыяласына кагылуга, тимер-томырларын төяп, елгага юл алды.* Ф.Җамалетдинова

**ТИМЕРХУТ** *и. тар.* Тимер тәгәрмәчле арба. *Шуннан Таҗи абзый кучер булып китте, тимерхут башында, кукраеп, пар атта гына йөри башлады!* Ш.Маннур. *Капканы чыгуга, аларны тимерхутка сылу озын гәүдәле күк айгыр җигелгән, утыргычта өлкәнрәк яшьтәге кучер утырган «экипаж» көтә иде.* Р.Сибат

**ТИМЕРЧЕ** *и.* Тимердән һәм башка металлардан төрле әйбер ясау һәм аларны төзәтү белән шөгыльләнүче оста. *Баш бирми торган юргаларны, аргамакларны берүзе станга кертеп, тавышсыз-гаугасыз дагалый торган тимерче тирә-якта бер булса, Сабит Йосыф улы шундыйларның берсе, атаклысы иде.* А.Гыйләҗев. *Назаровка халкы чалгыны да кибеттән алмый. Авыл тимерчеләре аны станда коеп, чүкеп, чыныктырып, үзләре ясыйлар.* А.Хәсәнов

**ТИМЕРЧЕЛЕК** *и.* 1) Тимерче һөнәре яки шөгыле; тимердән төрле җайланмалар, кораллар һ.б. ясау эше. *Леспромхозда чакта ул тимерчелек эшенә аз-маз өйрәнгән.* Г.Әпсәләмов. *Алтын Урда чорында болгарларда әле монголларга кадәр үк барлыкка килгән һөнәрләрнең бар төрләре дә үсешен дәвам итә: тимер кою, тимерчелек, бакыр кою, зәркәнчелек, --- туку, сөяк кисү, киез басу һ.б.* Б.Хәмидуллин

2) *к.* **тимерлек**. *Аннары, төркем күздән югалгач, тимерчелеккә кире кереп, бүленгән эшенә тотынды ---.* М.Галәү. *Хезмәт укытучысы тимерчелектә якорь ясатып алган, ә пионервожатый кулына йозак сыман бер нәрсә тоткан иде.* А.Тимергалин

**ТИМЕРЧЫБЫК** *и.* **1.** Диаметры бөтен озынлыгында тигез булган металл чыбык. *Немецлар тәмам исләрен җыйдылар: чәнечкеле тимерчыбык буена вак мина белән тондыра башладылар.* Х.Камалов. *Сәгатьнең озын тимерчыбыкка эленгән борчак коймагы төсле сары теле уңга-сулга талгын гына чайкалмаса, Бикташ аны йөри дип тә белмәс иде, чөнки уклары, сумала белән ябыштыргандай, хәрәкәтсез булып тоелды.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Шундый чыбыктан эшләнгән. *Монтажчылар беренче карашка үрмәкүч пәрәвезедәй чәбәләнеп беткән тимерчыбык йомгаклар белән мәш киләләр.* М.Хәсәнов. *Канәгать берничә тапкыр үзе ясаган тимерчыбык кармаклар белән селәүчәнгә кармак салып карады ---.* А.Хәлим

**ТИМЕРЬЮЛ** *и.* 1) Рельсларны шпалларга беркетеп, поездлар йөрү өчен ясалган махсус юл. *Күбесенчә кытай белән японнардан торган пассажирлар тимерьюллар тирәли тезелеп киткән алачыкларга кереп китәләр дә, кырмыскалар сыман күтәренеп, калага ашыгалар.* В.Имамов. *«Мәскәү – Казан» тизйөрешле тимерьюл магистрале «Евразия» коридорының төп линиясенә керәчәк, --- дип хәбәр итә «Коммерсант».* Мәйдан

2) Транспортның шундый юлны файдалана торган тармагы. *Тимерьюл больницасы артындагы өйләренә җиткәч тә, мәшәкатьләр шактый булды.* Мәдәни җомга

**ТИМЕРЬЮЛЧЫ** *и.* Тимер юлларны салуда, төзәтүдә яки тимерьюл транспортында эшләүче кеше. *Өстендә тимерьюлчылар кия торган ак төймәле кара шинель, башында форменный фуражка, тик кокардасы алынган.* Г.Әпсәләмов. *Пакгауз билгеле бер сәгатьтә түгел, ә шушы юлны карап, ремонтлап торучы тимерьюлчылар бригадасы килеп чыкканда гына ачыла икән.* А.Хәсәнов

**ТИМЕ́Р ЭШЕ** *и.* Тимерче һөнәре, тимерчелек. *Мин өйрәттем әтиеңне тимер эшенә.* З.Зәйнуллин. *Тимер эшеннән тыш оста калайчы да, агач эшенә дә, мич чыгарырга да – һәрнәрсәгә кулы ятып тора.* З.Мәхмүди

**ТИМПАН** *и. гр.* 1) Шөлдерле барабан һәм тамбуринга охшаган борынгы бәрмә музыка коралы

2) *архит.* Фронтонның рәсемнәр яисә скульптуралар белән бизәлгән ярымтүгәрәк яки өчпочмак формасындагы эчке кыры; ишек яки тәрәзә өстендәге стенаның эчкә батып торган өлеше. *--- тимпаннарда телле-телле, алты һәм сигез кырлы гипс розеткалар ясалган.* Казан утлары

**ТИМРӘ́Ү** *и.* Вак кына кутырлар, тимгелләр чыгу белән характерлы булган кычулы тире авыруы. *Ярымъялангач тәннәрен корчаңгы, тимрәү --- баскан кешеләрнең берешесе ике катлы, аслы-өсле --- агач ятакларда утырып-ятып тора ---.* Т.Галиуллин. *Урам этләре авыл башындагы чүплектә актарынып йөри. Кыяфәтләренә карап торырга куркыныч. Кайсында тимрәү, кайсы борчалы, кабыргалары гына күренеп тора.* М.Заһиди

**ТИМРӘҮЛЕ** *с.* Үзенә тимрәү йоккан; тимрәве булган. *1 аш кашыгы коры үләнне 1 стакан кайнар суда 1 сәгать төнәтеп, тимрәүле урыннарга ябарга.* Сөембикә. *Сыеклыкны тимрәүле урыннарга сөртсәң, йогышлы кабарчыклар кибеп юкка чыгачак, яңалары барлыкка килми.* Ватаным Татарстан

**ТИМСАХ** *и. гар. зоол. иск.* **1.** Крокодил. *Төшеңдә тимсах, ягъни крокодил күрсәң, дошман ул, диелә «Төхфәтелмөлек»тә.* Ф.Яхин. *Дөге-дөге яшен түгеп еглый икән корбанына якынлашкан тимсах та...* З.Мансуров

**2.** *с. мәгъ.* Крокодил күненнән яки шуңа охшатып эшләнгән. *Тимсах туфли. Тимсах чемодан*

**ТИМТЕНҮ** *ф.* 1) Омтылу, талпыну. *Ә бит эскадронның политругына бу хакта алдан ук әйтергә, сөйләшеп киңәш сорарга ничәмә тимтендем. Юк, оялдым, курыктым, тел әйләнмәде!* Ш.Маннур

2) Хәлдән килгән кадәр, булдыра алганча эш башкару, тырышу, маташу. *Җыянша абый белән Хөснулла абый да, әллә кайчан эшкә керешеп, ярыйсы гына тимтенеп яткан булалар иде.* Ш.Маннур

3) Авырлык белән яшәү, дөнья көтү. *Тимтенсәң дә кимсенмә.* Мәкаль

**ТИМУРЧЫ** *и.* Тимурчылар хәрәкәтендә катнашучы. *Әле бездә тимурчылар командасы да бар, нәкъ әүвәлгечә*

*әби-бабайларга ярдәм итәләр*. Л.Гыймаева. *Кайда ул тимурчылар, матросовчылар, яшь гвардиячеләр, Павлик Морозовлар, Зоя Космодемьянскаялар? Әгәр патриотлык хисе, тимурчылар булса, бүгенге кыргый күренешләр булмас --- иде*. Н.Галиев

**ТИМУРЧЫЛЫК** *и.* Пионерларның картларга, ятимнәргә һ.б.ш.га ярдәм итүне, үрнәк пионерлар тәрбияләүне максат итеп куйган, 1940 елда оешкан хәрәкәте. *Без, III «В» группасы студентлары, ике ел инде Сәләй ага һәм Рәмзия апаларга, бик теләп, кайбер йорт эшләрендә булышырга барабыз. Совет системасы теле белән әйткәндә, «тимурчылык» эшенә йөрибез.* Р.Зарипов. *Гап-гади бер китапның чыгуы илдә тимурчылык хәрәкәтен барлыкка китергән, ул хәрәкәт пионериянең һәм комсомол оешмасының төп эшләренең берсенә әйләнгән.* Татарстан яшьләре

**ТИНТӘК** *с. гади с.* **1.** 1) Аңгыра, ахмак, юләр, бер үк вакытта бәйләнчек, үзсүзле, үҗәт һәм холыксыз (кешегә карата әйтелә). --- *ахмаклар токымы тиле администраторлар яки тинтәк генераллар белән генә чикләнми.* А.Тимергалин. *Үзе бик шат, үзләренчә нидер мыгырдана, тинтәк кеше сыман, тик торганда кычкырып-кычкырып көлгәләп куя.* В.Нуруллин

2) Уйланылмаган, мәгънәсез. – *Сөйдергеч ясатканмы әллә берәрсе? – дигән тинтәк сорау телемнән ычкынганын сизми дә калдым*. А.Гыйләҗев. – *Миңа акча кирәкми, ә нигә миңа акча? – дип, гаҗәпләнүеннән тинтәк сүз әйтеп ташлады*. З.Мурсиев

**2.** *и. мәгъ.* Ахмак, тиле, мәгънәсез кеше. *Нинди матур тормышны бозды бит ул, тинтәк!* Г.Әпсәләмов. *Болай да инде, Васяга акча салганнан бирле, монда мине тинтәккә саныйлар.* Ф.Яруллин

**ТИНТӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Тинтәк булып китү, тинтәккә әверелү. *Мәхәббәтеннән тинтәкләнгән Хәбир фәлсәфә сатарга керешә*. Ш.Хөсәенов. *Бүгенге көндә ирен өйдә көтеп утырган хатын я эчкечегә, я фахишәгә әверелә, я тинтәкләнә, яисә дин юлына баса*. Тамаша

2) Тинтәклек эшләү, тинтәкләрчә кылану. *Бәхеттән безнең баш әйләнмәде: борын күтәреп тинтәкләнмәдек.* Х.Туфан. *Рәтләп йөртә белмәгән көе, тинтәкләнеп, шушы Чүкәйгә тикле килгәне өчен, тагын үзен битәрләргә тотынды*. В.Нуруллин

**Тинтәкләнә бару** Торган саен тинтәклегә арту. *Җыеннарда гомергә куркып утырасың, тамактан аш үтми: галиҗәнапның кинәт кенә шушы очракка туры китереп шигырь әйтүеңне таләп итүе ихтимал. Шуның өчен миеңне тартылган җәя кебек көне-төне әзер тотасың, туктаусыз киеренкелектән тинтәкләнә барасың.* Җ.Ильясов

**Тинтәкләнә башлау** Тинтәкләрчә кыланырга тотыну

**Тинтәкләнеп алу** Бераз, берара тинтәклек күрсәтү

**Тинтәкләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй тинтәкләнү

**Тинтәкләнеп йөрү** Озак вакытлар тинтәкләнү. *Моңарчы да шул анасының... тәти кызы Рухия дә Рухия дип тинтәкләнеп күп йөрде инде ул!* В.Нуруллин

**Тинтәкләнеп калу** Нинди дә булса сәбәптән соң тинтәкләнү. *Кешеләр югалып, тинтәкләнеп калгандай булдылар.* К.Миңлебаев

**Тинтәкләнеп тору** Әле, күз алдында тинтәклек күрсәтү

**ТИНТӘКЛӘРЧӘ** *рәв.* Тинтәкләр кебек, тинтәк кешеләргә хас булганча. *И-и улым, бетмәдә шул тинтәкләрчә кыска уйлап кырт кисүең!* С.Шәрипов. *Гаиләсе белән кавышу ирне акылыннан яздырган, күрәсең. Ул, тинтәкләрчә, әле дөньяда атасы белән анасыннан башка берничә кешене генә таныган малаена --- урынсыз киңәшләрен бирүне дәвам итте*. Р.Гаязетдин

**ТИНТӘКЛЕК** *и.* 1) Тинтәк булу; тилелек, юләрлек. *Хатынының эшкә киткәнен генә көтеп тора да, үзе кебекләрне җыеп, өйнең асты өскә килгәнче типтерәләр. Ә бер көнне, аның шушы тинтәклегеннән файдаланып, ниндидер очраклы кешеләр аларның үзләрен дә чистартып чыктылар.* Р.Сәгъди

2) Тинтәкләрчә кыланыш, уйлап-нитеп эшләнмәгән эш. *Байтүрәнең сүзләрен башына сыйдыра алмады, сабыр, мәгәр ачулы тавыш белән аны бүлде: – Син, – диде, – акыл белән, баһадир ирлек белән гомер иттең. Инде ахыр көнеңдә бер тинтәклек кылыйм дип ятканыңмы бу?!* Г.Ибраһимов. *Авыз чите белән генә елмаеп, улының тинтәклегенә шаклар катып карап торган Рәхимә, теләсә нишләсен дип, кул гына селтәде.* Х.Ибраһим

**ТИНТЕРӘТҮ** *ф.* Йөдәтү, аптыратып бетерү, теңкәгә тию. *Заһит абыйны кара тиргә батырганчы тинтерәтеп тә бернинди юньле мәгълүмат ала алмагач, офицер Хәйруллага: – Ташла, барыбер рәт чыгачак түгел бу ахмактан!* В.Нуруллин. *Истә-уйда юк нәрсәләр башыма кереп тинтерәтә.* М.Хуҗин

**Тинтерәтә башлау** Тинтерәтергә тотыну. *Зәйтүнә иң элек үзе җилкәсендәге шәлен салып чөйгә элде, аннары Иргалине чишенергә өндәп тинтерәтә башлады*. М.Хәсәнов. *Кызларның да күзе кыза, читкә китәм дә читкә китәм дип, әти-әниләрен тинтерәтә башлый*. Р.Вәлиев

**Тинтерәтә бирү** Тинтерәтүен дәвам итү. *Без, сыер савучылар --- бүген, иртәгә ни эшләсен белеп торабыз. Ә алар киләләр дә, тегене эшләгез, моны эшләгез, дип тинтерәтә бирәләр*. А.Вергазов

**Тинтерәтеп алу** Бераз, берара тинтерәтү. *Ләкин Малютинның карашыннан ук тойдым: аның әле минем үземне бераз тинтерәтеп алырлык хәбәрләре дә бар икән.* З.Зәйнуллин. *Киләчәктә --- оппозициянең күренекле вәкилен тинтерәтеп алу мөмкинлеген Кремль кулдан ычкындырмас.* И.Сираҗи

**Тинтерәтеп бетерү** Тәмам, бик нык тинтерәтү. *Барча врачларны тинтерәтеп бетерде.* Х.Камалов. *Казанда бала табу йортлары да тинтерәтеп бетерде, аларның да артык балалардан арынасы килә.* Ф.Яруллин

**Тинтерәтеп тору** Һәрвакыт тинтерәтү. *Туктаусыз тинтерәтеп торуларын шуның белән дә аңлатып буладыр, мөгаен.* Мәйдан. *Табигатьтә гаделлек юк. Адәм баласын һәрвакыт тинтерәтеп торган тагын бер нәрсә – гаделлек эзләү*. Шәһри Казан

**ТИНТЕРӘ́Ү** *ф.* Аптырау, йөдәү; йончу, тилмерү, җәфалану. *Туган җирдән рәнҗеп, авырлык, кимлек-хурлыклардан*

*тинтерәп күчеп килүчеләр шундыйларны аеруча еш көйләгән, күрәсең.* Т.Әйди. *Эшсезлектән тинтерәп аптырагач, мәктәп чакыруы буенча укучылар белән очрашуга да йөреп карады ул.* З.Хөснияр

**Тинтерәп бетү** Тәмам, бөтенләй тинтерәү. *Кичне көтеп ала алмыйча тинтерәп бетте Гази.* М.Хәсәнов. *Ул озак кына күрсәтелгән сумманы оештыра алмыйча тинтерәп бетте.* А.Вергазов

**Тинтерәп йөрү** Озак вакыт тинтерәгән халәттә булу. *Кыскасы, авызларын ачып, башларын күтәреп, әледән-әле алан-йолан як-якка каранып, шактый озак тинтерәп йөрделәр.* Р.Кәрами. *Билгесезлек хәлендә тинтерәп байтак йөргәч, көннәрдән бер көнне Матбугат йортына килеп кердем.* Р.Вәлиев

**Тинтерәп калу** Берәр тәэсирдән соң тинтерәү. *Әрнеп-сызланып, ни дияргә дә белмичә тинтерәп калдык.* М.Хәсәнов. *Әби аларның сүз табалмый тинтерәп калуларына игътибар итмәде.* А.Әхмәтгалиева

**Тинтерәп тору** Әле, хәзер тинтерәгән хәлдә булу

**ТИҢ** *с.* **1.** 1) Биеклек, тирәнлек, киңлек, озынлык кебек үлчәмнәр буенча билгеле бер нәрсә белән бертигез, яки шуңа тәңгәл, бердәй, охшаш. *Син дә бай, Мөхәммәдьяр бәк, синең дә сарайга тиң йортларың бар ---.* Р.Батулла. *Йөзектәге асылташлар йолдызларга тиң, ефәкләре дулкын-дулкын диңгезгә тиң.* Ф.Яруллин

2) Озынлыгы нинди дә булса бер урынга, тәңгәлгә җитеп, тиеп торырлык, берәр нәрсә белән тигез. *Саклар өчен зифа буен яман күздән, Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан.* Дәрдемәнд

3) Билгеле бер сыйфат ягыннан бердәй, бер үк төрле. *Татар халкы борын-борыннан «Кешеләрдән кешеләр һич ким түгел, тик бәхеткәйләре тиң түгел» дип белми җырламагандыр.* Т.Галиуллин

4) Яшь, буй-сын, дәрәҗә яки абруй кебек сыйфатлары ягыннан кемгә (кем белән) булса да тигез, бердәй. *Хәзер Гобәйдуллам исән булса, нәкъ Габдуллага тиң булыр иде.* Ә.Фәйзи

5) Бер-берсенә торырдай, бер дәрәҗәдәге, үзара иш. *Сын дисеңме үзендә, гыйффәтлелек вә мөлаемлык дисеңме, акыл турында әйтеп тә торасы килми – падишаһларга тиң фикер иясе.* Р.Батулла. *Сине беренче тапкыр күргәч үк, улыма: «Бу интернат килмешәге сиңа – яхшы ата-ана баласына тиң түгел», – дип әйттем.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* Үзенә ярашлы, тиңдәш, иш зат яки әйбер. *Ул бит кеше күзе төшмәслек егет түгел, теләсә нинди хәлдә дә үз тиңен таба ала.* Ф.Бәйрәмова. *Әнә [сыерчыкларның] берсе коймa буендагы сирень куагына кунган да яз җырын җырлый, үзенең парын эзли. Парын эзли, кошлар да үз тиңен эзли шул.* И.Сираҗи

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Нинди дә булса кыйммәте, сыйфаты ягыннан берәр нәрсәгә охшап, шуны алмаштырырлык рәвештә. *Чирәмгә ашъяулык җәеп, иркен табында кайнар кәбабны икәве тәмләп ашадылар – сый ашына тиң булып кызган икән куырма.* М.Хуҗин. *Адәм балаларын бөҗәккә тиң кую дөрес түгел, минемчә.* М.Маликова

2) Бергә, берьюлы. *Ул Фрәңгизнең ике аягын тиң кочаклады.* Р.Батулла. *Зыр-зыр әйләнгән пычкы секунд эчендә аның ике бармагын тиң өзеп ыргытты...* Ф.Абдуллин

3) Бер дәрәҗәдә. *Гәрчә кояш үзенең нурларын һәммәбезгә тиң сипсә дә, арабызда Нариманның тәне тизрәк каралып өлгерде.* К.Миңлебаев

◊ **Тиңе юк** Башкалардан күпкә өстен. *Эшкә дисеңме, уен-көлкегә дисеңме, җыр-биюгә дисеңме – авылда гына түгел, бөтен тирә-якта аның тиңе юк иде.* Г.Әпсәләмов. *Кибернетика, атом, электроника, лазер, химия! Әмма аның аты тирә-юньдә тиңе юк төрекмән аргамагы була.* Т.Әйди. **Тиңе булмаган** *к.* **тиңдәшсез**. *Әйе, мәхәббәт иде ул, тиңе булмаган ялкынлы мәхәббәт көч бирде Нурҗиһанга кыенлыкларны җиңәргә!* Г.Бәширов. *Менә шул Атласның Рөстәм исемле олы улы, ягъни Солтанхәкимнең оныгы, шушы Магнит даласында дөньяда тиңе булмаган мәчет төзетте.* Ф.Бәйрәмова. **Тиңе күрелмәгән** *к.* **тиңдәшсез**. *Тиңе күрелмәгән эшлеклелек, чиксез галәм масштабындагы колач, гади акылирешмәслек исәп-хисап!* И.Юзеев. *Кабул итү, каршы алу – бер нәрсә, иң мөһиме: халык йоласы, бездә гадәтләр шундый, дигән сылтау белән кунакка зур суммада ришвәт төртә белү иде. Бу өлкәдә полковник тиңе күрелмәгән оста булып чыкты да.* Р.Мирхәйдәров. **Тиңе табылмаган** *к.* **тиңдәшсез**. **Тиң килү** Берәр сыйфаты белән кем яки нәрсәгә булса да охшау, шуңа тиңдәш булу. *Мәхәббәт бит ул бер-берсен яхшы белгән, тиң килгән кешеләр арасында гына була.* Ә.Еники. – *Инде хәзер, кызым, буй-сыныңа тиң килерлек эш табарга кирәк,* – *дигән аңа бер көнне әнкәсе һәм үзенең танышбелешләре, туган-тумачалары, кода-кодачалары аша җайлы һәм майлы эш эзли башлаган.* Ф.Яруллин. **Тиң күрү** Тиңсенү, тиң итеп карау, тиңдәш санау; кимсетмәү. *Ата-ана, әби-баба, бөтен зур нәсел моңа сөенеп риза булды, күрше егетен тиң күреп, үз арасына алырга әзерләнде.* Ф.Бәйрәмова. *Хатын-кыз күп, кай арада кыюланып өлгергәннәр, ир-ат белән тиң күреп сөйләшәләр: эштә дә, ашаганда да бергә.* Г.Якупова. **Тиң күрмәү** Тиң итеп карамау; кимсетү. *Ул үзе дә минем кебек бер билгесез кешене тиң күрмәс күк тоелды.* Г.Әпсәләмов. *Мине тиң күрмәсәң дә, мин әйткәннәрне бу юлы тыңла.* Т.Миңнуллин

**ТИҢГЕНӘЙ** *и. этн.* Унике ахирәт кызның берсе; гомумән ахирәт, якын кеше. *Минем тиңгенәем бик акыллы иде*

**ТИҢДӘШ** *и.* **1.** 1) Кемгә дә булса кордаш, яшьтәш кеше. *Бераз каранып торганнан соң, яулыкны бер почмагыннан тотып, әле генә бергә уйнаган тиңдәшләрен югалткан баладай, нәүмизләнеп, елыйсы килеп, палубаны акрын гына әйләнеп чыкты.* Ә.Еники. *Соңгы вакытта Нәби бөтенләй геройга әйләнде. Үги анасы белән тәмсезләнешеп, бер рөхсәтсез ярты ай Мәскәү каласында йөреп кайткач, тиңдәшләре арасында абруе бик нык үсте аның.* Х.Ибраһим

2) Кемгә дә булса билгеле сыйфатлар белән тиң булган шәхес, җан иясе. *Ә шагыйрьләр, шундый зур шагыйрьләр, миңа үзләренең тиңдәшләре, каләмдәшләре итеп карый.* Ф.Яруллин.

*Әйтерсең шушы әчке аваз кинәт кенә пыр итеп оясыннан очып чыккан коштай күктә талпына, җиһанны иңләп канат кагына, үзенә тиңдәш рухын эзли.* Н.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Замандаш, яшьтәш булган. *Аны үзенең яшь вакыттагы бер тиңдәш дусына охшата...* Ш.Камал. *Күңелем минем мәңге ямансулар, Хисләренә тиңдәш яр сорар.* Р.Батулла

2) *лингв.* Җөмләдә формаль яктан бердәй функцияне үти торган. *Татар теле дәресеннән өйгә эш итеп «тиңдәш кисәкләр» бирелгән иде.* М.Мәһдиев. *Җыючы теркәгечләр җөмлә эчендәге тиңдәш кисәкләр янында киләләр ---.* Татар теле морфологиясе

3) Охшаш, бердәй, тиң. *Фәкать шул чагында гына син әлеге мәкальнең нинди очракларда кулланылуын аңлап, үз телеңдә дә әнә шуңа тиңдәш мәкальне яки әйтемне сайлап ала алырсың.* К.Миңлебаев

**ТИҢДӘШЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Тиңдәш итеп, тиң күреп, тиң санап. *Сынавын узганнар тиздән аның туганы шикелле якын кешесенә әвереләләр: ул алар белән тиңдәшләрчә гап-гади сөйләшә, хәлләрен сораша, иҗатлары белән ихластан кызыксына.* Р.Хәмид

**ТИҢДӘШЛЕК** *и.* 1) Тиңдәш булу. *Күккә үрли Бөек Тукай моңы, Тиңдәшлеген раслап ал таңга! Ләкин Тукай үзе тиңсез кала Гел әрнештән торган Ватанда.* Ф.Гыйззәтуллина

2) Тигезлек, тиңлек, ишлек. *Ходай белән тиңдәшлекне җирдә Тик мәхәббәт бүләк итәр безгә.* Л.Шагыйрьҗан

**ТИҢДӘШСЕЗ** *с.* **1.** Алыштырырлык, чагыштырырлык тиңе булмаган. *Күрче, зинһар, үзенең дөньяда тиңдәшсез, җаныннан газиз изге җан Гөлүсәсен нинди бәхетсезлекләргә дучар иткән бит ул.* М.Хәсәнов. *Ике яктан да бер мең бишәр йөз танк катнашкан бу тиңдәшсез бәрелешне һәр ваклыгына чаклы хәтерли ул.* А.Вергазов

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик тә, үтә. *Бу вакыт аның гадәттә дә тиңдәшсез матур күзләрендәге ялкыны вә шигърияте әллә ничә кат артык балкып, яңакларында алсу ут яна, йөзендә гаҗиб илаһи бер нур уйный башлый.* Г.Ибраһимов. *Әмма адәм баласы өчен үз өең, үз куышың белән, --- үз гаиләң, үз туганнарың белән яшәү тиңдәшсез зур бәхет икән.* А.Хәсәнов

**ТИҢЕННӘН** *бәйл. к.* **тиңентен**. *Бакча башыннан әйләнеп төшсәм, ни күрәм: ап-акларым, йомшакларым абзар артындагы өеп куелган тирестә кайнашалар, бил тиңеннән дә, бөтенләй дә кирә-кирә, тирес суалчаны табып ашыйлар иде.* Р.Гариф. *Авылга кергәнче, Абу бабага тез тиңеннән кар ерып барырга туры килде.* Казан утлары

**ТИҢЕНТЕН** *бәйл. сөйл.* **1.** 1) Билгеле бер биеклеккә, бер тәңгәлгә кадәр. *Өйләрнең күбесен түбәләре тиңентен көрт басып киткән.* М.Галәү. *Бер генә яһүд тә виноград үстерми, балык та тотмый, тез тиңентен су ерып, дөге дә җитештерми.* М.Хәбибуллин

2) Чаклы, хәтле. *Җир тиңентен җирне сатсак та, тик бер нәрсәне – ул да булса сугыш кораллларыбызны сатмыйк.* Ф.Дәүләтбаев

**2.** *рәв. мәгъ. сир.* Үзара охшаш халәттә, бертөрле, бердәй, бертөсле рәвештә. *Беләсезме, бүген Нәби абый белән Гөлҗиһан апаны кавыштырабыз бит. --- Икесе ике тиңентен кавыша алмыйча саргаеп-кибеп йөриләр ич.* Р.Төхфәтуллин

**ТИҢЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса икенче кеше яки әйбер белән бердәйләштерү. *Мин үземне еш кына бөек фантаст язучы Жюль Верн белән тиңлим.* А.Хәсәнов. *Өлкә ОБХСС башлыгы Нурматовка чины буенча туры телефон куелырга тиеш булмаса да, ул куярга кушты, шулай итеп, аны бюро члennарына тиңләде.* Р.Мирхәйдәров

2) Охшату, чагыштыру. *Укый-яза белмәгән кешене сукырга тиңләде.* М.Хәсәнов. *Хәер, нигә мин бу ирне гөнаһсыз ерткыч хайваннарга тиңлим әле.* Н.Гыйматдинова

**Тиңләп карау** Тиңләргә тырышу, чагыштыру. *Ул безнең арабызда караштырып йөрде-йөрде дә, минем яныма басып, үзенең буен миңа тиңләп карады.* Г.Бәширов. *Игенчелекне завод-фабрика гамәленә тиңләп карыйлар.* Х.Камалов

**Тиңләп кую** Алдан тиңләү. *Кан басымын көйләүче, авыртуны басучы йөрәк даруларын еш кулланырга мәҗбүрләрне махсус тикшеренүләр алкоголиклар һәм наркоманнарга да тиңләп куя икән.* А.Галимов

**Тиңли башлау** Тиңләргә тотыну. *Ул инде үзен күптәннән җимешсез калган ялгыз агачка тиңли башлаган иде.* Г.Галиева. *Эстрада җырчысы сәхнәдә бөтерелеп тормаса, халык аны ветераннарга тиңли башлый.* К.Кәримов

**ТИҢЛӘШТЕРГЕСЕЗ** *с.* Үз ишләреннән өстен булган, чагыштыргысыз, тиңе юк. *Бу башында безнең иске кара мунчабыз тора, аны ягып керү һични белән тиңләштергесез тән рәхәте һәм рухи канәгатьлек бирә.* Казан утлары

**ТИҢЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Чагыштыру, чагыштырып карау. *Аерым билгеләре буенча әйберләрне һәм күренешләрне бер-берсе белән тиңләштерү, тәңгәл кую һәм аларның охшаш якларын күрсәтү чагыштыру алымының нигезендә ята.* Ф.Гафурова. *Әмма без үзебезне, гадәттә, башкалар белән чагыштырабыз, бигрәк тә Америка Кушма Штатлары белән тиңләштерәбез.* С.Кутушев

2) Бердәй итеп, тиң итеп күрү. *[Баймөрат:] Араларында оҗмах хуры кебекләре бар, ди. [Шәйхезаман:] Тәүбә әстәгъфирулла, диген, мулла Баймөрат. Оҗмах хурлары белән тиңләштерүең урынсыз.* Т.Гыйззәт. *Вәлиди Тукай шигърияттенә объектив бәя бирә, Толстой белән тиңләштерү сизелми, бары Толстой һәм Мәгарри иҗатларында күзәтелгән әхлакый караш һәм фәлсәфи инануның аз булуына гына басым ясый.* З.Мөхәммәтшин

**Тиңләштерә башлау** Тиңләштерергә тотыну. – *Авырга узганнан соң, хәтта Сәриямә тиңләштерә башлаган идем бит, юләр, – дип, йөзе буйлап тәгәрәп төшкән күз яшьләрен сөртеп алды ул.* Г.Галиева

**Тиңләштереп карау** Чагыштыру максаты белән тиңләштерү. *Ниһаять, бер сүзгә килеп, теге Чин патшасының кызын хибестә ята торган шаһзадә янына хәзер үк алып килергә дә матурлыкларын бер-беренә тиңләштереп карарга булдылар.* К.Насыйри. *Ничә елларга сузылган шәһәр тормышыннан соң авылга торырга дип кайтуын ул,*

*аяк очлары белән капшанып, кыядан түбән төшүгә тиңләштереп карады.* Ә.Гаффар

**Тиңләштереп куюю** Көтмәгәндә, сирәк кенә тиңләштерү. *Сәбилә әллә Хәербарны кояшка тиңләштереп куйды инде.* З.Мурсиев

**ТИҢЛӘШҮ** *ф.* 1) Үзара тиң булу, кем яки нәрсә беләндер тигезләшү, бердәй дәрәҗәгә җитү. *Алар шундый бай яшәгәннәр: дөньяда аларның байлыгына беркем дә тиңләшә алмаган.* Н.Фәттах. *Дөньяда бер генә кыз да сиңа тиңләшә алмый, Миләүшә.* Ф.Яруллин

2) Билгеле бер тәңгәлгә, сызыкка, зурлыкка җитү. *Фатыйманың кинәт аяклары йөрмәс булды, баскан җирдә таш булып катты. --- Солдат Фатыймага килеп тиңләшкәнче, урыныннан кузгала алмыйча катып тора бирде.* З.Кадыйрова

3) Кем яки нәрсә белән булса да бердәйлекне аныклау. *Йорт алдында нәрсә очратсам, шуңа тиңләшеп йөрим.* Ә.Бикчәнтәева

4) Ярышу. *Бүген хуҗалыкның алдынгы савым осталары Мария Аксакова, Татьяна Захарова белән тиңләшеп эшли икән ул.* Авыл офыклары

**Тиңләшә бару** *к.* **тиңләшеп бару**. *Традицион рәвештә үткәрелә торган үзешчән сәнгать смотрлары шуны раслый: кайбер коллективлар үзләренең осталык дәрәҗәләре буенча профессионалларга тиңләшә баралар.* Казан утлары. *Хәзерге җәмгыятьтәге ятимлек тә аңа тиңләшә бара.* Туган як

**Тиңләшеп бару** Тиң булу дәрәҗәсенә якынаю. *Чынында Гөмбә «агулы» булып чыкты: файдасы – чебенгә, зарары филгә тиңләшеп бара түгелме?* Т.Галиуллин. *Кеше гомере чебен гомере белән тиңләшеп бара.* Татарстан яшьләре

**Тиңләшеп бетү** Тәмам, бөтенләй тиңләшү. *Ирина үзе дә балалар белән тиңләшеп бетте.* Казан утлары

**Тиңләшеп җитү** *к.* **тиңләшеп бетү**. *Йорт-җире, каралты-курасы ягыннан күршесенә тиңләшеп җитәм дигәндә генә, гөнаһ шомлыгына, мунчасы янып китте.* Яңарыш

**Тиңләшеп калу**Ниндидер вакыйгадан соң тиңләшү. *Шуннан бирле бала үлеме минем өчен иң куркыныч әйбергә тиңләшеп калды.* Авыл офыклары

**Тиңләшеп карау** Тиңләшергә тырышу. *Минем шикелле фермада эшләп карасын ул! Миңә аннан соң тиңләшеп карар!* С.Зыялы

**Тиңләшеп килү** *к.* **тиңләшеп бару**. *Хәзер без җандагы Хозурлык, зурлыкта Тиңләшеп киләбез тауларга.* Ф.Гыйззәтуллина. *Авылда шәхси «Газель»ләр һәм сөт ташый торган машиналар ике дистә чамасы, хосусый тракторлар да райондагы кумәк хуҗалыкларда булганнар санына тиңләшеп килә.* Ватаным Татарстан

**Тиңләшеп тору** Вакытлыча тиңләшү; һәрвакыт, гел яки хәзер, сөйләү моментында тиңләшү. *Тиңләшеп тормый шул күңел Заман калыпларына, Ашкынып дөнья куабыз Нәфес тарафларына.* Сөембикә

**ТИҢЛЕК** *и.* 1) Тиң булу сыйфаты. *Төннәрен көндез итәрлек балкый синең йөзләрең, Анда [башка] йөзләргә тиңлек күрмәдем.* Ф.Бурнаш. *Тикмәгә генә укытучысы кәтиб Хафиз, бер күзгә-күз карашып алу дүрт мәгънәне аңлата, дип әйтми икән: йөрәк ачкычын, күңел теләгген, җан тиңлеген, әйтер сере барлыгын.* М.Хәбибуллин

2) Тигезлек. *Фарукҗан митингҗыелышларда, матбугатта хатынкыз ирегe, тиңлеге хакында күп ишетсә дә, күп укыса да, аларның никахка каршы да баш күтәрүе белән әле болай күзгә-күз очрашканы юк иде.* Т.Әйди

**ТИҢСЕЗ** *с.* **1.** 1) *к.* **тиңдәшсез**. *Сарайда тиңе булмаган тәхет корылып, аның ике ягында муеннарына кызыл якуттан муенсалар таккан унар тиңсез гүзәл кыз утыра.* К.Насыйри. *Фәргать гарип кешеләрнең яшәүгә дәртләре көчлерәк икәнлеген аңлады, ул алар арасында тормыштан зарланып, уфтанып утыручыларны очратмады. Монда һәр көн, һәр минут яшәү өчен тиңсез көрәш бара иде.* Ф.Бәйрәмова

2) *сир.* Үзара тиң, иш булмаган (ир белән хатын һ.б.ш. тур.)

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиңеннән башка. *Синсез үтә, тиңсез үтә Иртәләрем, кичләрем.* Х.Туфан

2) Чиктән тыш. *Аерым алганда, ритм, рифма өлкәсендәге яңалыклары, ачышлары белән татар шигъриятен тиңсез баетты, бу өлкәдә аның белән ярыша алырлык шагыйрьләр бармак белән санарлык.* Т.Галиуллин

3) Тиңе, тормыш иптәше булмыйча. *Авыр бу дөньяларда тиңсез яшәве*

**ТИҢСЕЗЛЕК** *и.* Тиңсез булу, тиң булмау. *Кемнәр ничектер, әмма мин үзем аның булганлыгына, осталыкта тиңсезлегенә соклана идем.* Ф.Яхин. *Аның иҗатының бөеклеген, тиңсезлеген исбатлый торган төп сыйфатларның берсе – татар халкының җанлы сөйләм телендә иҗат итүе.* Г.Галиуллина

**ТИҢСЕНҮ** *ф.* Үзеңне кемгәдер тиң, иш күрү, бер дәрәҗәдә итеп санау. *Кызларны гына түгел, үзебезнең мәктәп малайларын да бик тиңсенәсе килмәде Зәйнәпнең.* Л.Ихсанова. *Карап-карап торам да, кем, мелла, кашларыңны җыергалап, минем тәкъдимемә каршы килергә җыенган сыман итенәсең. Нәрсә бу? Безне тиңсенмәү түгелдер ич?* М.Хәсәнов

**ТИП** I *и. диал.* Зур түгәрәк кысага тарттырылган күннән гыйбарәт музыка коралы; бер мембраналы барабан, зур төңгер. *Типкә типмә – балаң елак булыр.* Әйтем

**ТИП** II *и. гр.* 1) Бериш әйбер яки күренешләрнең өлгесе, үрнәге саналган әйбер яки күренеш; төр, модель. *Бу типтагы немец көймәсенең алты торпеда аппараты белән кораллануы аңа билгеле иде.* Г.Әпсәләмов. *20 нче елларда Г.Нигъмәти яңа типтагы совет мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару буенча да күп эшли.* М.Мәһдиев

2) *биол.* Үсемлек һәм хайваннар классификациясендә үзара кардәш классларны берләштергән иң югары бүленеш. *Хайваннарның хордалылар тибы өч зур төркемне берләштерә ---.* Зоология. *Бөҗралы суалчаннар, яки бөҗралылар тибы, суалчаннарның башка типлары вәкилләре белән чагыштырганда, шактый катлаулырак төзелешле 9 мең чамасы төрне үз эченә ала.* Биология

3) Кыяфәт, йөз һәм гәүдә төзелеше яки холкы, кыланышлары бердәй

булган кешеләрнең билгеле бер төре. *Билалның андый тип кешеләрне күргәне бар: алар һәрчак үтә җитди булып күренергә тырышалар, үзләренә кеше алдында (ә бәлки, һәрвакыт шулайдыр!) бернинди тегенди-мондый малай-шалайлык, беркатлы кыланмыш рөхсәт итмиләр.* М.Вәли. *Мондый типларның һәр икесе чын кеше булудан ерак тора.* Ф.Сафин

4) *әд*. Кешеләрнең нинди дә булса социаль төркеменә хас булган характерлы билгеләрне әдәбият яки сәнгать чаралары белән гомумиләштереп күрсәткән нәфис образ. *Шамил – төрле үзенчәлектәге образлар, бигрәк тә күпсанлы тискәре типлар иҗат иткән күренекле артист.* И.Илялова. *Төп герой Нуриасма – һәр авылда яшәгән «ак чәүкә» кебек, халык күзенә дә, җитәкчеләр күзенә дә ерактан күренеп торган аерым бер тип.* Ә.Низаметдинов

5) Тискәре яки сәеррәк холкы белән аерылып торган кеше. *[Карачәч:] Соня, Сонечка, минемчә, бу типның кесәсендә ике бакыр тиене дә юк. Психушкадан куылган бомж.* Ф.Яруллин. – *Мин телефонны өзеп куйган идем. – Нигә өздең соң син аны? – кызның сүзләрендә гаҗәпләнү тойгысы яңгырады. – Әллә нинди сәер типлар шалтыратып теңкәгә тиеп беттеләр.* З.Мәхмүди

**ТИП-** *кис*. «Т» хәрефенә башланган кайбер сүзләргә ялганып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә (мәс., *тип-тигез* һ.б.). *Һәй, симәнке! Һәй, ирис! Акча бирсәң – тип-тиген.* Х.Туфан. *Әкрен генә түгел, тип-тиз генә Җитеп килә Питрау көннәре.* К.Булатова

**ТИПАЖ** *и. фр.* 1) Нинди дә булса әйбернең типлар, модельләр җыелмасы. *Тезмә ургычларның типажы аларны агрегатлау ысулын, алым киңлекләрен һәм башка техник күрсәткечләрне исәпкә алып эшләнгән.* Урып җыю машиналары. *Самолётлар типажы. Тракторлар типажы*

2) Кайбер тип кешеләргә яисә иҗтимагый катламга хас билгеләр җыелмасы. *Бомжлар арасында искиткеч кызык типажлар очрый. Йөзе җимерек, авыз читендә бердәнбер теше тырпаеп торган, йөзен аркылыга-буйга җыерчык баскан сукбайның бәхетле елмаюы ни тора!* Г.Гыйльманов. *Без милли типажларда артык дәрәҗәдәге талантлылык күрергә теләмибезме?* М.Сәлимҗанов

3) Рәссам, скульптор, фотограф һ.б. өчен модель ролен үтәүче үзенчәлекле тышкы кыяфәткә ия кеше. *Ике дистәгә якын портрет әзер. Эшләве аңа авыр булмады: әллә балачак еллары узган Кураиш үзе нindидер тылсым белән илһамландырып тордымы, әллә инде кешеләре шундый иде, рәссамнар теле белән әйткәндә, һәр йөз – менә дигән типаж.* З.Мурсиев // Әдәби әсәрдәге үзенчәлекле билгеләре белән аерылып торган тип; гомумиләштерү объекты итеп алынган образ. *Очерк та этюд кебек. Ул язылачак зур әсәр өчен характер, типаж, вакыйга эзләү һәм табу өчен кирәк.* И.Гази

4) Кыяфәте, буй-сыны, уйнау үзенчәлеге белән билгеле рольләргә туры килә торган актёр. *Рольгә кирәкле типаж эзләү*

**ТИ́ПИК** *с.* 1) Билгеле бер предмет, шәхес, күренеш тибының характер үзенчәлекләрен үзенә алган, үзендә чагылдырган. *Шулай да кайбер тәнкыйтьчеләр Зөфәр Сабитовны безнең җәмгыять өчен типик түгел дип таптылар.* Ә.Еники. *Ә дөньяны аңлау, аңа мөнәсәбәткә килгәндә, бу персонажлар арасында әллә ни аерма юк: аларның һәммәсен янәшә куеп, билгеле бер чор яшьләр буынының типик сыйфатларын берләштергән характер дип бәяләргә мөмкин.* А.Гыйләҗев

2) Гади, гадәти, гадәттәге, еш очрый торган. *Миңа, хәтеремдә фильтрдагы кебек әһәмиятле яки типик хәлләр генә калсын өчен, хәтеремнең сюжетны сөзеп чыгаруы кирәк.* М.Хуҗин. *Бер халыкның төрле компонентлардан оешуы – тарихта бик типик күренеш, закончалыклары да билгеле.* Р.Әхмәтьянов

3) Әдәбиятта һәм сәнгатьтә тип булып саналган. *Шаһбаз белән Солтан – ярлы крестьян сыйныфын гәүдәләндерүче типик образлар.* М.Хәсәнов. *Гафуриның хикәя төзү һәм типик характерлар тудыра алу осталыгыннан, иҗтимагый тормышның эченә һәм кеше психологиясенә тирән итеп керү алымнарыннан күп кенә файдалы нәрсәләр өйрәнә алалар.* Н.Юзиев

**ТИ́ПИКЛАШТЫРУ** *ф.* Сәнгатьтә һәм әдәбиятта типик образ тудыру, сурәтләргә типик үзенчәлекләр бирү; сәнгатьчә гомумиләштерү. *Озак та үтми, шагыйрь бу шәхескә яңадан әйләнеп кайта. Бу юлы ул аны типиклаштыру юлы белән бирә.* М.Мәһдиев. *Сәнгатьнең һәр конкрет күренешне гомумиләштерү (типиклаштыру) сәләте бар бит әле.* К.Гыйззәтов

**ТИ́ПИКЛЫК** *и.* Типик булу үзлеге. *Бу классик уен кораллары Казан татарлары тарафыннан кулланылганлыгы очраклы булмавын, аларның типиклыгын башка чыганаклар да исбатлый.* Г.Макаров. *Үз башыннан үткәннәрне әнә шулай бәян итү барышында Ирек байтак башка шәхесләрне дә искә ала, ягъни бу фаҗигаләрнең типиклыгын бирүгә ирешә.* Әдәбият

**ТИПКЕ** *и. гади с.* Кыйналу, җәберләнү, кыерсытылу хәле; кемнең дә булса кыйнавы, җәберләве, кыерсытуы, читкә кагуы. *Төкерер идем авылга. Тормышмыни бу, яшәүмени? Шәйхулла типкесендә йөр инде.* А.Гыйләҗев. *Кечкенәдән үк --- еш кына салып кайтып тавыш чыгара торган әтисенең әре, типкесе астында үскән кеше.* В.Нуруллин

**ТИПКЕН** I *и.* 1) Елганы бугач яки язгы ташкын вакытында суның күтәрелү, җәелү күренеше; ташу. *Су юлы ачылу белән баржаларны тизрәк ходка җибәрү максатыннан чыгып, язгы ташкын вакытында типкен астында кала торган урыннарга склад ясау практикасы күптән бар, имеш.* М.Әмир. *Сипкел булып борыннарга, Типкен булып болыннарга яз килә.* Казан утлары // Суны бугач, агымның кирегә борылу күренеше

2) Кояш һәм Ай йогынтысы белән диңгез суының күтәрелеше; *русчасы*: **прилив**. *Вә диңгезләр гашыйк булмаса, һәр көн Нигә шаулар, гөрелдәр иде типкен?* Котб

3) *күч.* Һөҗүмгә кискен каршылык, һөҗүмне кайтару. «*Таулар» пьесасында*

*аларның [корткычларның] эшләренә типкен бирелү күрсәтелә.* Г.Нигъмәти

**ТИПКЕН** II *с. иск.* Корбанын бик оста тотып ала торган (ау кошлары тур.). *Кем бар үткен, аты чапкын, кошы типкен – Кызыбыз Аембикә шуңа булсын.* Н.Исәнбәт

**ТИПКЕНЛЕК** *и.* Кимсетелеп, кыерсытылып яшәү, типкедә булу. *Әтиең юк шул инде, ии балам! --- Ятимлектә, типкенлектә узармы икән гомеркәйләрең...* Ф.Дунай

**ТИПЛАШТЫРУ** *ф.* 1) *тех.* Билгеле бер типка кертү; бердәйләштерү, унификацияләү. *1979 елда «Очу аппаратлары җитештерүче махсус средстволарны проектлаганда, эксперимент элементларын типлаштыру» темасына диссертация яклый, техник фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе ала.* Г.Мөхәммәтшин. *Технология процессларын типлаштыру. Машина детальләрен типлаштыру*

2) *к.* **типиклаштыру**. *Сәнгатьле гомумиләштерү, типлаштыруларда да әдип яңа югарылыкларга күтәрелә.* М.Гайнетдин. *Мәгълүм ки, фольклорның кайсы гына жанрын тикшерә башлама, иң элек бу жанрдагы әсәрләрнең сюжетларын типлаштыру, системага салу, ягъни классификация таләп ителә.* Л.Җамалетдинов

**ТИПО́ГРАФ** *и. гр.* Типографика белгече. *Мөхәммәд Идрис – Мөхәммәд Ибраһим улы Идриси (1882–1948), атаклы хаттат (каллиграф), хәреф кисү-кою остасы, типограф.* Г.Исхакый. *Татарча китаплар бастыручы танылган типограф Харитонов ун еллар элек аңа матур язу остасыннан хәреф бизәкләрен эшләткән иде.* М.Вәлиев

**ТИПОГРА́ФИК** *с.* Типографика эшенә караган; типографикага бәйләнешле. --- *Гамил абый Афзалның «Гомер кичүләре» дигән бик затлы типографик басмада «Рухият» нәшрияты чыгарган шигырь китабы ачык тәрәзәдән очып кергән кош кебек көтмәгәндә килеп керде.* Ф.Яруллин. *Типографик җиһазларның заманча ук булмавына --- һәм башка төр кыенлыкларга карамастан, нәшрият андый нәфис китапларны укучылар кулына әледән-әле бүләк итеп тора.* Р.Фәйзуллин

**ТИПОГРА́ФИКА** *и. гр.* График һәм шифр дизайнына нигезләнгән язма текстны бизәү сәнгате. *Башкортстан Фәннәр академиясенең «Фән һәм сәнгать» күргәзмәләр залында «The Type Directors Club» шрифт һәм типографика халыкара күргәзмәсе ачылды.* Кызыл таң

**ТИПОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Газета-журнал, китап басыла торган урын; басмаханә; матбага. *Бигрәк тә ул типография шрифтын камилләштерү өчен көрәшә.* М.Мәһдиев. *Типография, кәгазь, хәреф җыючылар, хәтта корректорлар да аныкы иде.* Г.Гомәр

**ТИПОЛО́ГИК** *с.* 1) Типологиягә бәйләнешле. *Ихтимал ки, татар-болгар мәҗүсилегендә иген-җөгәрә тәңресе булгандыр (андый тәңре булу – типологик күренеш).* Р.Әхмәтьянов. --- *хәтта географик яктан бер-берсеннән бик ерак торган халыкларның әкиятләрендә дә охшаш урыннар очрый. Болар – типологик характердагы уртаклыклар.* Л.Җамалетдинов

2) Типология кагыйдәләре буенча бүленеп гомумиләштерүгә яисә классификацияләүгә нигезләнгән. *Әйтик, япон теле белән татар телендә охшаш сүзләр булуы әллә ни гаҗәп түгел ди, чөнки япон теле белән төрки телләр типологик яктан бертуган исәпләнелә.* Н.Фәттах

**ТИПОЛО́ГИЯ** *и. гр. махс.* Предметларның яки күренешләрнең иң мөһим уртак билгеләре буенча фәнни классификациясе. *Телләр типологиясендә бу күренеш күбрәк эш-хәлнең үтәлү рәвешен, үтәлү характерын белдерә торган аспектуальлек чарасы буларак билгеләнә.* Ф.Хисамова. *Әмма сакланып калган шактый күп язма, тарихи мәгълүматлар, төрле тасвирламалар зекернең типологиясен һәм ислам дөньясында реаль урынын билгеләргә, ул традицияләрне реконструкцияләргә мөмкинлек бирәләр*. Г.Макаров

**ТИПТӘР** *и. фар.* 1) *тар.* XVII–XX гасырларда Көнчыгыш Татарстан һәм Башкортстан территориясендә формалашкан рус булмаган халыклардан (башлыча татарлардан) торган хәрби сословие вәкиле; *русчасы*: **реестровый казак**. *1926 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, типтәрләрнең саны 27,4 мең булган, аннан соң, халык санын алганда, типтәрләр аерым төркем итеп каралмаган: алар татар, башкорт, мари, мордва булып язылганнар.* А.Тимергалин

2) *этногр.* Башлыча хәзерге Башкортстан территориясендә яшәүче Көньяк Урал татарларының этник төркеме. *Сезнең авыл халкы татар булса, татарның кайсы кабиләсеннән (казан татары, касыйм татары, мишәр, типтәр, төмән, алатыр һ.б.)?* Гали Рәхим

3) *иск.* Исемлек, реестр

4) *тар.* Рус казаклары арасындагы татар (мишәр) отрядлары

**ТИПТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тибү** I (*1–3 мәгъ.*). *Тренер пенальти типтерә*

2) Тибәргә мөмкинлек бирү яки рөхсәт итү. *Бәпкәләрне тилгәннән типтерү*

3) *күч.* Кәеф-сафа кору; күңел ачу. *Хис дигәннең х хәрефе дә юк икән аңарда. Алай гынамы, ул малайлар белән уңга да, сулга да типтерә икән.* А.Гыйләҗев. *Гыжгылдап беткән көенә үзенең кызыннан яшьрәк булган чибәр хатын белән типтереп кайтмакчы!..* В.Нуруллин

**Типтерә башлау** Типтерергә тотыну. *Тагын бер елдан режиссёр абыйлары үзенең студенткасы – Башкортстаннан килгән бер кыз белән ачыктан-ачык типтерә башлады.* Р.Кәрами. *Җарияләр гарәп-фарсы хадимнәре белән типтерә башлаганнар, балалары туса яшергәннәр.* В.Имамов

**Типтерә тору** Даими рәвештә, әледән-әле типтерү. *Шулай типтерә торгач, ул хатынның беркемгә дә кирәге калмый.* Р.Батулла

**Типтереп алу** Кыска вакыт арасында типтерү. *Без, ахрысы, беркөнне бу турыда күбрәк уйлаганбыз: төшкә кайткач, классташым Рәкыйп белән үзара киңәштек тә нәкъ шулай бер «типтереп» алырга булдык.* М.Мәһдиев. *Студент тормышы лекция тыңлау яисә имтихан тапшыру кебек мәшәкатьләрдән генә тормый бит, кесәң калын булганда кәеф-сафа корырга,*

*типтереп алырга да мөмкинлекләр бирә.* Х.Ибраһим

**Типтереп йөрү** Озак вакытлар типтерү. *Яшь чакта үзе сыман типтереп йөргән кызларның, бик шома гына, ансат кына яхшы егетләргә кияүгә чыгып рәхәт чигүләрен белә ич ул...* З.Хөснияр. *Аннан соң, мин өйдә саргаеп ятканда, син типтереп йөрер идең бугай!* Сабантуй

**Типтереп калу** Үз вакытында, мөмкинлектән файдаланып типтерү. *Бердән, аңа әле егерме алты гына, яшьлегенең кадерен белеп, ни кылганса – шул килешә өйләнмәгән егеткә дип, типтереп калу форсатын кулдан ычкындырасы килми.* Р.Кәрами. *Хатын-кызны аңламассың. Берәүләре, фронтта тере ирләре була торып та, типтереп калу ягын гына карый.* Н.Әхмәдиев

**ТИПЧАК** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан тар кыяклы һәм тар себеркәчле, мал азыгына китә торган үлән. *Кулга ияләштерәсе җир – көрәк күрмәгән кара туфрак – узган елгы типчак, кылган, әрем ише әрсез үләннәр, язга чыккач, каракура болынына әверелгән.* К.Кәримов

**ТИПЧҮ** *ф.* Энә белән эре-эре атлатып кулдан тегү. *Кияү аңа кисүдә булышты. Типчегәндә, теккәндә, кайбер вакыт ике кисәкне беркетеп тотып ярдәмләште.* Г.Ибраһимов. *Бишмәт иске, сиңайтим, уң җиңендә ямау да күкрәк турысында ямау. Әнкәсе типчегән, эре генә инә белән.* Н.Гыйматдинова

**Типчеп алу** Тиз генә типчү

**Типчеп бетерү** Барысын да яки ахырына кадәр типчү

**Типчеп кую** Алдан типчеп, әзер хәлгә китерү. *Минә шушы оекны типчеп куй әле, кызым...* М.Галәү. *Кесәң түбен кисәме?.. Онытмыйча әйт бичәңә: Типчеп куйсын кесәңне...* Г.Морат

**Типчеп чыгу** Тиешле урыннарның барысын да типчү. *Бөркет күзе белән инәсенә җеп саплап, җеназага баргандә сүтелеп, таралып китмәсен өчен, кәфенне берничә урыннан типчеп чыкты.* А.Хәлим. *Бизәкне, уң ягында яхшы беленерлек итеп, ак җеп белән типчеп чыгабыз.* Сөембикә

**ТИР** I *и.* Кешенең һәм хайваннарның тире асты бизләре бүлеп чыгарган бүлентек. *Юл-юл тир агып төшкән какча йөзендә ап-ак тешләре белән күзләре генә елтырый.* А.Тимергалин. *Хәер, бер атлап, бер йөгереп барудан аңа хәтта эссе була башлады, аркасына ябышкан күлмәгә су сеңүдән генә түгел, тир бәреп чыгудан да юеш иде.* А.Вергазов

◊ **Тиргә бату** Эсседән, авыр эштән нык тирләү; бик ару. *Ә кояш чамадан тыш кыздыра башлады. Атлар тиргә батты ---.* Г.Әпсәләмов. *Әле ярый көне кыздыра, югыйсә ничек киптерер идең тиргә баткан башыңны?* В.Нуриев. **Тир кату** Тир парланып бетеп, тән суына төшү. *Габделбәр, --- хайваннарының [атларның] тире каткач, якындагы инеш буена илтеп арканлады да үзе казык төбенә сузылып ятты.* М.Шабай. **Тир(не) киптерү** Берәр кызу эшне туктатып ял итү; эштән тукталып тору. *Егетләр көндезен күләгәдә тир киптереп яткан әрәм вакытның каруын кайтарырга чын-чынлап керештеләр.* Р.Төхфәтуллин. **Тир салу** *к.* **тир түгү**. *Илдә барган кырыс шартларда бу хакта җитди уйланып, реаль гамәлләр башкарырга кирәк. --- Һәм ошбу юнәлештә һәр татар, кайда яшәвенә карамастан, тырышып, җиде кат тир салып эшләргә тиеш.* Фән һәм тел. *Әнә шулай зур тырышлык, үҗәтлек күрсәтеп, күпме көч һәм тир салып башлады эшен фермер Гайнетдинов.* Кызыл таң. **Тир түгү** Бик зур көч куеп, бик тырышып яки бик авыр эш эшләү. *Гөләндәм кала тирәсендәге бер төзелешкә барып урнашты. --- Ипинең беркайда да ансат кына бирелмәвен, аны тир түгеп табарга кирәклеген шунда төшенде.* А.Гыйләҗев. *Әмма бу байлыкларын Ногайбәкләр урлашыпалдашып түгел, ә тир түгеп, тырышлык белән тапканнарын үзе күреп тора бит.* А.Хәсәнов

**ТИР** II *и. фр.* Пневматик яки кул утлы коралларыннан атырга өйрәнү өчен махсус бина яки бүлмә. *Бәләкәй бакча аша үткәндә, тирда мылтык атып торучы үсмерләргә күз салды.* А.Гыйләҗев. *Габделнур белән Гөлзәрия, тирга барып, пневматик мылтыктан аттылар, дөресрәге, башта егет үзенең бәхетен сынады.* Р.Кәрами

**ТИ́Р АВЫРУЫ** *и. к.* **тиф**

**ТИРА́ДА** *и. фр.* Сөйләмнең, гадәттә диалогның, озын һәм артык ясалма күтәренкелек белән әйтелгән фразасы; реплика. *Хәйдәрнең Равилә турындагы тирадалары тәмам туйдырды. Минем өемдә сәгатьтән артык һаман шуны сөйләшәләр ---.* Р.Хәбибуллина. *Испан телендә сөйләшүче дәртле, кызу яңа танышларының тирадаларын теләсә ничек аңла!* Сөембикә

**ТИРАЖ** *и. фр.* 1) Бастырып чыгарылган китап, газета-журнал һ.б.ның нөсхәләр саны. *Ана телебездә укучылар кимеде. Китап, газета-журналларның тиражы шуны раслый.* Р.Фәйзуллин. *«Авторның язма рөхсәтеннән башка копия ясау тыела. Тиражы 10 данә. Яңа Чәчкап авылы. 2005» диган язманы укып, ирексездән көлеп куйдым.* Р.Батулла

2) *сөйл.* Китап, газета-журнал һ.б.ның барлык нөсхәләре җыелмасы. *Берүзе, материал җыеп, мәкаләләр язган, Мәскәүгә килеп, типографиягә тапшырган һәм, бөтен тиражны күтәреп кайтып, баракларда, брезент палаткаларда өләшеп тә йөргән ул.* Т.Биктимирова

3) Лотереядә яки заёмда отышларны билгеләү чарасы. *Осоавиахим лотерея билетларының һәр тиражы уйналган саен, Гәрәй почтага йөгерә.* А.Алиш. *Заёмнар артыннан бер-бер артлы һәртөрле лотерея тиражлары чыгара башладылар.* Татарстан яшьләре

4) Заём облигацияләренең һәм башка шундый бурыч кәгазьләренең, түләнеп, үз көчләрен югалтуы. *Облигацияләр тиражга чыгу*

◊ **Тиражга чыгу** Искерү, яраксыз хәлгә килү, кулланыштан чыгу, кирәксезгә әйләнү. *Нишләптер, бу үзен язучы дип танытткан агайны аның телевизордан да күргәне юк, шулай ук трибуна-мазардан да фамилиясен ишеткәне юк. Күрәсең, тиражга чыккан бер Алла бәндәседер инде.* Ә.Еники. *– Һәр клиент белән аракы чөмерә башласаң, бер атнада тиражга чыгуың бар, – дип куәтләде аны Шура. Аз сүзле Марина*

*да: – Ә тиражга чыгар көннәребез алда әле, – диде.* А.Хәсәнов

**ТИРАН** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы Грециядә һәм XIII–XVI гасырларда Италиядәге шәһәр-республикаларда берүзе идарә иткән хаким, хөкемдар. *Ләкин Гистиэй исемле грек аңа каршы чыга: «Дарий хакимияте урнашу аркасында, – дип башлый ул сүзен, – безнең һәркайсыбыз шәһәрләрдә тиран (хаким) булып тора ---». Гистиэйның чыгышы грек тираннарының иң авырткан җиренә кагыла ---.* Борынгы төрки халыклар тарихыннан хикәяләр

2) *күч.* Башбаштак һәм шәфкатьсез идарәче, дәүләт башлыгы һ.б.ш. *Власть башына наданнар, деспотлар, тираннар килгән.* Т.Миңнуллин. *Адәм баласының үзгенә үткән кайбер тираннарның, хаиннарның да исеме тарихта кала.* С.Шәрипов

**ТИРАНИ́Я** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы Грециядә һәм XIII–XVI гасырларда Италиядәге шәһәр-республикаларда абсолют, бернәрсә белән дә чикләнмәгән, тулы хакимияткә нигезләнгән идарә итү формасы

2) Абсолют, чикләнмәгән хокукларга таянып, законсыз, башбаштаклык белән идарә итү формасы; деспотизм. *Гомеремнең иң бәрәкәтле булырга тиешле елларында, ягъни Джугашвили тираниясе булган елларда, миңа горбәттә, сөргендә көн күрергә туры килде.* Б.Урманче. *Литвалылар, латышлар, эстоннар! Сталин тираниясенә көчләп кертелгән илләр...* А.Гыйләҗев

3) *к.* **тиранлык**. *Без һаман да тормышның бу мәрхәмәтсез тираниясенә, каты аяусызлыгына кирәгенчә каршы тора алмыйбыз әле, без монда һаман да көчсез.* Г.Бәширов. *Моңа иң шатланган кеше Адилә булгандыр. Ул, ниһаять, Ирхан тираниясеннән котылды.* Р.Зәйдулла

**ТИРАНЛЫК** *и.* 1) Тиран булу, рәхимсезлек, шәфкатьсезлек

2) Тираннарга хас эш, гамәл, күренеш. *Ә кая соң кыю тарихи әсәрләр? Бөтен булганы игезәкләр кебек охшаш, ханнар ызгышы, бозык гыйшык, рус дәүләтенә яраклашу һәм тиранлык стихиясе белән булган таныш вакыйгаларның компилятив вариантлары.* Р.Фәйзуллин. *Троцкий үз чорында нәрсә дигән: «Без аны [Россияне] ак негрлардан торган чүлгә әйләндереп, шундый тиранлык күрсәтәчәкбез, хәтта ул Шәрыкның иң явыз деспотларының да төшенә кермәслек булачак!»* М.Галиев

**ТИРАРАЙ** *и. диал. к.* **камка** I. *Шырпы тартмасына тирарайлар җыяргамы? Межалардан җиләк эзләп караргамы?* Г.Бәширов

**ТИРАТАЙ** *иярт.* **1.** Җыр, такмак кебекләрдә ритмны, иҗек санын тотыру өчен кулланылган асематик сүз. *Тиратай, тиратай, Бер кияүгә бир, атай! Акчалары булмаса, Көтәчәккә бир, атай!* Җыр

**2.** *и. гади с.* Мәгънәсез шаян кеше; юньсез һәм шук бала. *Тыңламагыз шул тиратайны!*

**ТИРАТАЙЛАНУ** *ф. гади с.* Тиратай кебек кылану; шаяру, шуклану. *Я, тиратайланма инде, Заһирә, әйтсәң әйт.* К.Тинчурин

**ТИРӘ** *и.* 1) Билгеле бер ноктаның, предметның әйләнәсе, шуңа һәр яктан якын урын. *Тимер мич тирәсендә түгәрәкләнеп утырдык та, кулларны җылыта-җылыта, бөтен мәсьәләне шунда хәл иттек.* Г.Бәширов. *Озаклamый манара тирәсенә сөңге, җәя тоткан ир-атлар җыела башлады.* Р.Сәгъди

2) Әйләнә яки йомык күппочмаклык рәвешендәге фигураның чиге. *Күл тирәсендәге калын нарат һәм кедр урманын кистерә-кистерә өч сәгатьләп тырмашкач, агачлар арасыннан күлнең үзе күренде.* И.Хуҗин // Берәр нәрсәнең яны, ян ягы, әйләнәсе. *Монда эшеңне бетергәч, гараж тирәләрен чистартып куй!* А.Гыйләҗев. *Карт авыз тирәләрен, сакал-мыекларын сарган тир бөрчекләрен кул аркасы белән сөртеп алды.* А.Хәлим

3) Нәрсә дә булса урнашкан яки сүз сөрешеннән урыны аңлашылган җир, урын яки төбәк. *Башкорт җиренә күчеп утырган татар авыллары бу тирәдә инде байтак иде.* В.Имамов. *Бу тирәгә кеше бик аяк басмый, аста сазлык, халык җиләккә, печәнгә тау битенә йөри.* З.Кадыйрова

4) Нәрсәнең дә булса аерым өлеше. *Кемдер кырдан азык кайтара, --- башкалары каралты тирәләрен ремонтлыйтөзәтә...* Ж.Юныс. *Шуннан соң Заһир абый, сирәк кенә булса да, безгә килеп, ишек-тәрәзәләрне, абзар-кура тирәләрен рәтли торган булды.* М.Маликова

5) *күч.* Даирә, кемнең яки нәрсәнең дә булса эшчәнлек һәм тәэсир итү өлкәсе; гомумән эш яки шөгыль өлкәсе, тармагы. *Сәйфинең җыр яратуын һәм җырларга дәрте барлыгын белгәч, матур гына җырлаганын да ишеткәч, аны ул сәхнә тирәсенә тартырга тырышты.* А.Алиш. *Бу турыда шуны әйтергә кирәк: беренчедән, бу типлар, дөреслектә, язучылар түгел, ә әдәбият тирәсендә болганып йөрүчеләр генә иде.* М.Җәлил

6) *күч.* Сүз, бәхәс, әңгәмә кебекләрнең төп мәсьәләсе, тема. *Больницага бүген Казаннан яңа мөдир килергә тиеш. Сүз шул тирәдә бара.* Һ.Такташ. *– Берәр малайны җибәреп карасак? Фәритkә бу бик ошады: – Безнең уйлар бер тирәдә йөри икән, малай.* И.Диндаров

7) *к.* **тирәч**

**ТИРӘ́-ӘЙЛӘНӘ** *җый. и. к.* **әйләнә-тирә**. *Икмәк белән сулый бүген Бөтен тирә-әйләнә. Бүген хәтта кояшы да Охшап тора күмәчкә.* Р.Миңнуллин. *Тирә-әйләнәне кинәт кенә ялмап алып, гаять зур ялкын көлтәсе югары күтәрелә.* М.Яһудин

**ТИРӘК** *и.* 1) Гомумән зур һәм биек агач. *Сахраларга чыгып йөрсәм дә мин, Ял булмыйдыр янган йөрәккә; Әкрен генә тирән уйга чумам, Башым куеп ялгыз тирәккә.* Җыр. *Барып җитәләр бер алтын тирәккә.* Әкият. *Таш җәелгән киң сукмак буйлап бераз сөрлегеп барды да карт тирәккә килеп сөялде.* М.Хәсәнов

2) *бот. к.* **тупыл**. *Алар яшәгән урам бик киң һәм шау-шулы булып, каршы якта, биек каеннар һәм тирәкләр арасында, кызыл кирпечтән салынган борынгы чиркәү киңәеп, биегәеп тора.* М.Маликова. *Сикереп чыкмалы гына кара сулы инеш буендагы нәни тирәкнең бәпкә йонысдай мамыкларын каян искәне дә билгесез талгын җил тузгыта икән.* С.Шәрипов

3) *иск.* Тукымага чигеп яки басып төшерелгән үсемлекле орнамент.

*– Мәрфуга апа, бу чәчәк ни өчен кирәк булды сиңа? – Калфак тирәгенә.* Ф.Әмирхан

4) *күч.* Ата-баба нигезе; төп, туган нигез; байтирәк. *Тирәгең барда терәгең бар.* Мәкаль

**ТИРӘКЛЕ** *с.* 1) Тирәкләр үскән, тирәкләр булган. *Карт тирәкле, чал тарихлы зиратлары уйга салды.* М.Вәлиев. *Алар үскәндә чыр-чу килеп су кертә торган тирәкле яр да су астында калган.* Ә.Салах

2) Агачлы, үсемлекле орнамент төшерелгән. *[Хәмидә:] Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар.* Г.Камал. *Андый алъяпкычның «тирәкле алъяпкыч» дигән атамасы да билгеле.* А.Тимергалин

**ТИРӘКЛЕК** *и.* Тирәкләр күпләп үскән җир, тирәк агачлыгы. *Шулчак карашы алан читендәге тирәклеккә төште һәм, зиһене ачылып, кабат дөньялыкка кайтты.* Р.Рысаев. *Икенче көнне алар --- көмеш яфраклы тирәклекләр арасында йөрделәр.* Д.Каюмова

**ТИРӘ́-КҮРШЕ** *җый. и. к.* **күршетирә**. *Тирә-күрше һәркайсы: «Сәми абзый, инде син бөтенләй черегән бай булдың», – диләр.* Г.Камал. *Җитмештән үтеп баручы, гаять зур мәгълүматлы, Көектә генә түгел, тирә-күрше авыл халкының да хөрмәтен казанган Фарук мулла вәкарь белән генә михрабка үтте.* Г.Галиева

**ТИРӘЛӘЙ** *бәйл. к.* **тирәли**. *Картоннан кисеп, кызыл белән өртелгән биш чачаклы йолдыз, түшәмнең нәкъ уртасына асылып, тирәләй нурлар чәчеп торган бер рәвешкә кертелгән.* М.Фәйзи. *Малай, кулларын чәбәкәйләп, карт тирәләй биеде.* А.Хәлим

**ТИРӘЛӘП** *рәв.* **1.** Читләтеп, эченә кермичә. *Бу тәмугны үт син тирәләп.* К.Сатиев

**2.** *бәйл. мәгъ. Хакында, турында* сүзләрен алыштыра. *Кыз тирәләп яучы сөйләр, эш тирәләп ялчы сөйләр.* Әйтем

**ТИРӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса уратып, камап, әйләндереп алу, уртада калдыру. *Чамбәк углың Карлыгач тирмәсе янында тавыкны тирәләгән ярсу әтәч урынына бөтерелеп йөри.* В.Имамов. *Күрәсең, мал-туар зиратының кайчандыр киртәсе дә булган. Ә хәзер юк, тирәләп казылган һәм кычыткannан гайре берни үсми торган канау гына бар.* Ә.Гаффар

2) Чит, кайма тоту. *Кулъяулыкны челтәр белән тирәләү*

3) Эченә кермичә, әйләнеп, читләтеп яки якын килеп үтү. *Белә торып кузгалды, белә торып түрә сараен тирәләде, белә торып куштаннарына ялынды, күчтәнәч-бүләк ташытты, үтенечле хатлар яздыртты.* Д.Булатова

**Тирәләп алу** Тиз арада тирәләү. *Җыелган халык --- зур чананы тирәләп алды.* Г.Ибраһимов. *Монда басып торудан файда юк, кешеләр җыела башларлар, хәзер үк тирәләп алырлар.* Ә.Бикчәнтәева

**Тирәләп бетерү** Тирәләү эшен тәгәлләү. *Бакчаны тирәләп бетерде*

**Тирәләп кую** Алдан тирәләп эшен бетерү. *Карлыганны җыйгач, куакларын тирәләп куйган рамнарны алырга кирәк.* Бөгелмә авазы

**Тирәләп чыгу** Тулысынча тирәләү, рәттән барысын да тирәләү

**Тирәли башлау** Тирәләргә тотыну

**ТИРӘЛЕК** *и.* 1) Әйләнә-тирә, тирәюнь, табигый мохит. *Күнегелгән табигый тирәлектә генә тотрыклы рухи халәтне, яшәү дәртен һәм сәләтен саклау җиңел.* Т.Әйди. *Ул, беренчеләрдән булып, яңа шәһәрләр торгызуның, бөек төзелешләрнең, тирәлекне пычратуның киләчәк өчен нинди куркыныч алып килүен искәртте ---.* Т.Галиуллин

2) Гомумән, берәр урын һәм шуның тирәсе, шуңа якын җир. *Әни, аяксыз калып дүрт стена арасында утырса да, дөнья белән бергә яши, йортны уратып алган тирәлектән, авыл мәшәкатьләреннән, тормыш ыгы-зыгыларыннан аерыла алмый.* А.Вергазов. *Ул нәсел варислары бүген дә авылда һәм авылга якын тирәлектә ишле санала.* Л.Хәмидуллин

3) Билгеле үзлекләргә ия булган һәм берәр бушлыкны биләп торган матдә. *Махсус кристалл тирәлекләрдә сыну күрсәткечен үзгәртү ысулы белән фазалар синхронлыгын булдырып була.* Фән һәм тел. *Юл клинкеры һәм кислотага чыдамлы керамик эшләнмәләр зәһәр тирәлек (кислота, селте һәм органик эреткечләрнең сыек катнашмалары) тәэсиреннән саклый.* Төзү материаллары

4) Кеше яшәгән иҗтимагый мохит, даирә, чолганыш. *Бу очракта сәхнә сөйләме әйтелеше чолганыштагы әйтелешкә каршы куела. Шушы тирәлектә яшәүче тамашачылар бу каршылыкны тоймаска да мөмкиннәр.* Ф.Баязитова

5) *к.* **тирә** (*2 мәгъ.*). *Аның күңелендә үзе туып үскән бер тирәлек, ул тирәлекнең дә аерым бер урманы, яланы, чишмәсе, я булмаса тар гына бер авыл инеше яши.* Г.Сабитов

**ТИРӘЛИ** *бәйл.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең тирәсендә, әйләнәсендә. *Учак тирәли җиргә йомшак тиреләр җәелгән.* А.Хәсәнов. *Без кичләрен урман эчендәге кечкенә күл тирәли йөрергә гадәтләндек.* А.Әхмәтгалиева

2) Түгәрәкләп, әйләнә ясап. *Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли, Җир әйләнгән кебек кояш тирәли.* С.Сараи. *Горилла башта Таһир тирәли әйләнеп чыкты.* А.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Һәр яктан, һәр якка. *Сөнгать, тәрәзәгә барып, тирәли каранып, тәрәзәне чиртә.* М.Фәйзи

**ТИРӘН** *с.* **1.** 1) Өстән, өске яссылыктан, өсйөздән төпкә кадәр ара үлчәме зур булган; *киресе:* **сай** (сулыклар, чокырлар, шулай ук савыт-саба, баш һәм аяк киемнәре һ.б. тур.). *Менә карьерның бу почмагыннан балчык алып бетерәбез дә су җибәрәбез. Бик әйбәт, тирән күл.* А.Гыйләҗев. *Картларның берсе – кыска гына, юантык кына Әхмәтҗан бабай – аягына ак җон оек белән тирән галош, өстенә кыска сырма кигән ---.* Н.Фәттах

2) Калын катлам хасил иткән. *Тирән карны машинам белән ерып барып булмаячагы көн кебек ачык иде.* Ф.Яруллин. *Килдем сиңа монда җан алырга: Вакыт сиңа җансыз калырга, Тәнең тирән комга күмелергә, Җаның Тәңре алдына барырга...* Г.Сөнгати

3) Берәр нәрсәгә нык үтеп кергән; бик эчкә кергән. *Зур суларның күзгә*

*күренмәгән, күрер күзгә беленмәгән тирән агымнары бар.* Ш.Галиев. *Яңа нигездә яран гөлдәй тирән тамыр җәй, --- тормышыгыз шау чәчәктә булсын.* Т.Мөбарәков

4) *күч.* Колачлы, киң. *Ул [Сәфәрҗанов], сәхнәдә уйнаучы артистларча тирән жестлар ясап, --- декламация укы[ды].* К.Тинчурин

5) *күч.* Үзенең төп сыйфатында тулылыкка җиткән. *Аннары кухнядагы ут та сүнде. Кечкенә өй эче тирән караңгылыкка чумды.* Г.Әпсәләмов. *– Сугыш беткән, егетләр, сугы-ыш!!! – Кырда тирән тынлык урнашты.* З.Зәйнуллин. *Вагон эче тирән йокыда.* З.Хәким

6) *күч.* Нык яшерелгән, тиз генә табып, күреп яки аңлап булмый торган. *Ә ул: «Ашыгыч эшем бар иде», – дигән була, эчендәгесен үзе өчен генә тирән сер итеп саклый, күңелен беркемгә дә ачмый.* А.Вергазов. *Акыл ияләре адәм баласының дөньяда якты эз калдырып яшәвен хуп күрәләр, тереклекнең нәкъ менә шундыенда тирән хикмәт табалар.* Х.Мәхмүтов

7) *күч.* Тәэсире көчле булган (хисләр һ.б. тур.). *Күзләрендә гаҗәеп тирән моң, ә күңелләрендәгесен бер Ходай белә.* Г.Әпсәләмов. *Күңел төбен бик тирән кичерешләр биләве аның да йөзенә чыккан, соргылт-яшькелт күзләрендә чагыла.* А.Хәсәнов

8) *күч.* Бай, әтрафлы, колачлы. *Анна Афанасьевна торган саен татарчага күчә барганда, үзенең тирән белемен күрсәтеп калырга тырышкандай, ул торган саен урысчага күчте.* А.Хәлим

9) *күч.* Бай эчтәлекле, акыллы. *Хәтта иң тирән фикерле, талантлы замандашлары аны аңламаган; мондый үҗәтлеген өнәп бетермәгән чакларда, нәфрәтләрен дә ачыктан-ачык сиздергәннәр.* М.Гайнетдин. *Башта мин аны бик дәрәҗәле шахмат турнирларында катнашучы, үтә хәтәр йөреш алдыннан тирән уйга, исәп-хисапка, анализга чумган гроссмейстерга охшаттым, әй.* А.Хәсәнов

10) *күч.* Нинди дә булса эшнең һәр нечкәлеген яхшы белеп, җентекләп башкарылган. *Ул бөтен үткән сугышларның тарихын өйрәнеп, шуларга тирән анализ ясап, --- үз аң-акылы белән яңа хәрби тактика булдыру осталыгына иреште.* С.Поварисов

11) *күч.* Югары дәрәҗәдәге; эчтәлеге, кыйммәте ягыннан әһәмияте зур булган. *Тәүфикъ Әйди язмалары, тирән эчтәлекле булу белән бергә, җиңел укылышлы, мавыктыргыч булулары белән дә аерылып тора ---.* А.Гыйләҗев. *Галим бу сүзләр астында тирән мәгънә барлыгын төшенде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сай булмаган урын (суда, көпшәк массада). *Касаткин көлеп кулын селтәде дә тирәнгә йөзеп китте.* Г.Әпсәләмов

2) Эчке, аскы, төпке урын (катлам, нокта һ.б.). *Байлар суны тирәннән алып эчә. Сай кое – хәерчеләр коесы...* К.Кәримов. *Тамырлары тирәнгә киткән түгәрәк, бирчәйгән кабыклы төбе карт агачның ак бәгыре сыман ачылып китте.* М.Галиев

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Эчкә бик нык үтеп. *Бистәнең бөтен тирә-ягын тирән итеп казылган чокыр урап алган.* В.Имамов. *Бәхетенә, пычак бик тирән кадалса да, аңа әллә ни зыян китермәгән икән.* Татарстан яшьләре

2) Иркен, киң итеп. *Таһир тирән итеп тын алды.* А.Хәсәнов. *Рәфис җавап кайтармады, бары тирән итеп көрсенеп кенә куйды.* А.Вергазов. *Ә хәзер кәефләнеп, бер тирән итеп тәмәкесен суырды ---.* В.Нуруллин

3) Тиз генә табып, күреп яки аңлап булмый торган итеп. *Хисләрен, тойгыларын бик тирән яшерә ул.* Г.Гыйльманов. *Аның стеналары инде шактый иске булса да, биредә серләрне бик тирән саклыйлар.* Сөембикә

4) Белеп, аңлап, җитди итеп, җентекләп. *Яңа кешене җанлы итеп сурәтләү, – чынлап та, тирән тикшерелергә тиешле актуаль мәсьәлә.* М.Җәлил. *Вәсиләрнең бу хәрәкәте XX гасыр башында Е.В. Молоствова тарафыннан шактый тирән өйрәнелгән.* М.Мәһдиев

5) Тиешле дәрәҗәдә, төптән (уйлау, фикер йөртү, аңлау һ.б. тур.). *Хәзер халык бик тирән уйламаска, китаптан, бигрәк тә әдәби әсәрләрдән, рухи азык эзләмәскә өйрәнеп бара.* Г.Әпсәләмов. *Заманча радиостанция, күңел ачу белән беррәттән, кешегә мәгълүмат җиткерергә, рухи азык бирергә, тирән фикерләргә өндәргә тиеш, дип уйлыйм.* Д.Вәлиев

◊ **Тирәнгә җибәрү** Тагын да катлауландыру, кискенләндерү, киеренкеләндерү. *Габделнур сүзне тирәнгә җибәрмәс өчен елмаеп әйтте ---.* Р.Кәрами. *Башкортлар белән бәхәсне тирәнгә җибәрмәскә иде.* Р.Фәйзуллин. **Тирәнгә керү** Керешкәндәгедән, баштагыдан мөһимрәк мәсьәләләргә кагылу. *Менә шул дускай Хафиз, сүз ара сүз чыгып, үлем турында сөйли башлады. Мәсьәләнең тирәнгә кереп китәргә мөмкин икәнлеге хакында башына да китермәде ул.* В.Нуруллин. *Әңгәмәнең болай көтмәгәндә бик тирәнгә кереп китүе Әхтәм хәзрәтнең үзенә дә ошамады сыман.* В.Имамов. **Тирәнгә китү** Эш-гамәл, хәл, мәсьәлә һаман зурая, катлаулана, җитдиләнә бару. *Эшнең тирәнгә киткәнен сизеп, Нурулла дәшми, адымнарын тизләтеп, тизрәк моннан ычкынуын карый.* В.Юныс. *Югыйсә әлегә хәтле мөнәсәбәтләр болай ук тирәнгә китәр дип уйланылмаган иде.* М.Маликова. **Тирән йөзү** Нәрсәне дә булса бик яхшы аңлап, белеп эш итү, сөйләү яки фикер йөртү. *Ә инде Галимҗан кебек гыйлем диңгезендә тирән йөзәргә килүчеләр мантыйк кылын тарткалый башлагач, ул кылның тутыклыгы, өзелергә торуы сизелде.* С.Поварисов. *--- моңыбыз охшаш, япон аны үз йөрәге аша үткәреп утырды. Сораулар биреп аптыратты. Бу өлкәдә артык тирән йөзмәсәм дә, Такасима әфәндене канәгатьләндерерлек җаваплар кайтардым.* Г.Гомәр. **Тирән кесә** Акчасы күп, матди мөмкинлеге зур булу. *Кем ул тирән кесә, кемнеке ул кәкре бармаклар? Андыйлар булгач, нигә яшерәсең син аларны?* Г.Бәширов. **Тирән кичерү** Бик нык борчылу. *Фоат акылдан шаша язды, мин дә бик тирән кичердем.* И.Юзеев. **Тирән сукалау** *к.* **тирән йөзү**

**ТИРӘНӘЙТҮ** *ф.* 1) Тирән итү, тирәнгә әйләндерү. *Тирән чокырда мондый караңгы кичләрдә аерата сак булырга кирәк, аның җәенке төбенә ел саен яңа эз салабыз, ел саен аны язгы*

*ташкыннар тирәнәйтә ---.* А.Гыйләҗев. *Кояшта кипкән кавырсын савытларны, кыштырдык капчыкларны өем-өем җыеп яндырдылар, чишмәне тирәнәйтеп, ерганагын тигезләп, читләренә, убылмасын өчен, эре ташлар тезделәр.* А.Хәйртдинова

2) *күч.* Тулыландыру, арттыру. *Бөек Ватан сугышыннан соң Исмай Шәмсетдинов, музыкаль белемен тирәнәйтү нияте белән, Казан дәүләт консерваториясенең композиторлар факультетына укырга керә.* Ф.Шәмсетдинова

3) *күч.* Катлауландыру; җитдиләштерү. *Соңыннан, һаман-һаман теориясне тирәнәйтә барган саен, ул мәсьәләдә ачыклык күрә бардым...* А.Алиш. *– Әй, кем белгән инде аны... – дидем мин. Сүзне тирәнәйтәсем килмәде.* Р.Габделхакова

4) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса көчен, куәтен арттыру; кемне яки нәрсәне дә булса көчәйтү, көчле, ныклы итү. *Кайттың да яраны тирәнәйттең, хатирәләрне яңарттың.* А.Гыйләҗев. *Одикка нәрсә әйтергә? Юатыргамы? Юк, юк, ул аңа мохтаҗ түгел. Кирәкмәс вакытта юату – кайгыны тирәнәйтү генә ул.* Р.Сибат

5) *күч.* Аң-белемне киңәйтү, нигезле, дәлилле итү. *Дини йолага кагылышлы музыкаль мотивлар шәхси кичерешләрне, уй-фикерләрне тирәнәйтүгә юнәлтелгән; ул кешегә эчке мөстәкыйльлек һәм илаһи көч бирә.* Ш.Монасыйпов

**Тирәнәйтә бару** Торган саен ныграк тирәнәйтү. *«Красногвардеец»ны чолгап алган таулардан төшә торган кар, яңгыр сулары чокырны елдан-ел тирәнәйтә баралар.* Г.Әпсәләмов

**Тирәнәйтә башлау** Тирәнәйтергә тотыну. *Монахлар сөякләре алынып беткәч, экскаваторлар чокырны тирәнәйтә башлыйлар.* З.Зәйнуллин. *Мондый чакта, башта ятып торырлык окоп казыйсың, соңыннан аны тирәнәйтә башлыйсың.* И.Кашфразыев

**Тирәнәйтә төшү** Тагы берникадәр, бераз тирәнәйтү. *Шикле уйны инде бик ачык, бик якында моңланучы гармун тавышы тагын да тирәнәйтә төште.* К.Тимбикова. *Клара, ике бит уртасындагы, мине үзенә гашыйк иттергән чокырларын тагын да тирәнәйтә төшеп, тигез, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаеп алды.* А.Хәсәнов

**Тирәнәйтеп бетерү** Соңгы чиккә җиткереп тирәнәйтү

**Тирәнәйтеп җибәрү** Бераз, беркадәр тирәнәйтү. *Ул аның кып-кызыл иннеге ирененДәге җыерчыклары өстенә ягылып, аларны тагын да тирәнәйтеп җибәргәнлеген күреп алды.* Ф.Җамалетдинова. *Садыйкның караңгы кичерешләрен төнге яңгыр манзарасы тагын да тирәнәйтеп җибәрә.* З.Сәлахова

**Тирәнәйтеп карау** Тирәнәйтергә тырышу, тирәнәйтергә омтылу

**Тирәнәйтеп кую** Алдан тирәнәйтү, тирәнәйгән хәлгә китерү; кинәт тирәнәйтү. *Хәзер чокырны тирәнәйтеп куям.* А.Гыйләҗев. *Шул вакытта илаһи бер куәт тирәнәйтеп куя сулышны.* К.Сибгатуллин

**Тирәнәйтеп тору** Һәрвакыт, гел тирәнәйтү

**ТИРӘНӘЮ** *ф.* 1) Тирән булып китү; тирәнгә әверелү. *Апрель азаклары иде, кардан иртә ачылган сары йорт тирәсендә күлләвекләр күбәйде, чокырлар тирәнәйде, тузан өермәләре куерды.* А.Гыйләҗев. *Каюмны авыл тормышының авырлыгы ярыйсы бөккән: иңсәләр салынган, маңгай сырлары берсеннән-берсе тирәнәйгән.* А.Әхмәтгалиева

2) *күч.* Көчәю, ныгу, катлаулану, киңәю. *Серләр килешкәндә, фикер уртаклыгы булганда, ике затның хисләре бер учак булып дөрләгәндә, адәм баласының җаны рәхәт чигә. Акылы зирәкләнә, тойгылары тирәнәя бугай ул...* Б.Камал. *– Эшләр тирәнәя, – диде полковник. – Исән Вәлиев бу юлы ачыла төшкән.* Ш.Рәкыйпов

**Тирәнәеп бару** *к.* **тирәнәя бару**. *Алфавиттагы инде күпме сөйләнелгән шушы кимчелек аркасында сөйләм бозу кәсафәте буыннан-буынга күчеп, тирәнәеп бара.* Р.Мөхиярова

**Тирәнәеп бетү** Бик нык тирәнәю. *--- без моннан йөз еллар элек салынып, тирәнәеп беткән тәгәрмәч эзләре буйлап өскә менеп киттек.* Р.Вәлиев. *Юллар бик начар, хәрәкәт көчле, чокыр-чакырлар тирәнәеп бетте инде.* Хезмәт даны

**Тирәнәеп җитү** Тиешенчә тирәнәю. *Билгеле, ясалма киртәләр куелмаса, ниятләренә аяк чалмасалар, Әхмәтһади Максуди, иҗат дәрте ташып, белеме тирәнәеп җиткән дәвердә, тагын да күбрәк эш күрсәтә алган булыр иде.* Ф.Гаффарова

**Тирәнәеп калу** Берәр сәбәптән соң тирәнәйгән хәлгә килү. *Баязит абыйның күгелҗем күз чокырлары тагын да тирәнәеп калды ---.* А.Гыйләҗев. *Талларның тамыры белән җир күтәрелгәч, чишмә тагын да тирәнәеп калды.* А.Хәйртдинова

**Тирәнәеп китү** Кинәт тирәнәю. *Байтак вакыт су тездән югары күтәрелмәде. Аннары кинәт тирәнәеп китте, камышлар сирәгәйде.* Г.Әпсәләмов. *Дөрес, миңа эндәшкәндә, Иринаның тавышы үзгәреп, күңел түреннән агылгандай киңәеп, тирәнәеп киткәндәй була иде.* М.Маликова

**Тирәнәеп кую** Бераз вакытка тирәнәю. *Толикның ике бит уртасындагы бал кашыгы сыярлык кына чокырлары тагын да тирәнәеп куйдылар.* А.Хәсәнов

**Тирәнәеп тору** Һаман тирәнәю; тирән булып күренү

**Тирәнәя бару** Торган саен ныграк тирәнәю. *Кеше үзе өлкәнәйгән саен, йөзендәге җыерчык эзләре белән бергә, холык үзенчәлекләре, кимчелек буразналары да тирәнәя бара.* Ш.Галиев. *Ярты чакрым да үтмәде, мотоцикллар ясалма күлгә килеп керделәр. Алар да бара, су да тирәнәя бара.* Ф.Баттал

**Тирәнәя башлау** Тирәнәергә тотыну. *Су шулкадәр җылы, малайлар әйтмешли, май кебек. Тирәнәя башлагач, колачлап йөзеп киттек.* Н.Әхмәдиев. *Ярмөхәммәтнең карашы Алиһә күзләре белән очрашты, Алиһәнең күз алмасы, үзенә бер дөнья булып, киңәя-ачыла, тирәнәя башлады.* Р.Батулла

**Тирәнәя төшү** Тагын да ныграк тирәнәю. *Яңак сөякләре калку, киңчә ияк чокыры тирәнәя төшкән, керпе чәчләре арасында көмеш бөртекләр җемелди.* Н.Хәсәнов. *Фәйзария күңелендәге шомшик тагын да тирәнәя төште.* Р.Батулла

**ТИРӘНЛЕК** *и.* 1) Өстән иң төпкә кадәр ара, вертикаль үлчәмнең зурлы-

гы. *Ул телефон аркылы полк штабы белән хәбәрләшеп алды да, блиндаждан чыгып, кеше буе тирәнлегендә казылган аралашу юллары буенча пехотачылар янына китте*. Г.Әпсәләмов. *Омельченко ярты чакрымлы ташкүмер базында эшләсә, Патреевның эш урыны сиксәнтуксан метр гына тирәнлектәге сланец катламында икән*. Р.Кәрами

2) Бик зур пространство, чиксез киңлек; нинди дә булса тирәлекнең тирән урыны. *Монда инде --- икеләнеп тормыйсың: туп-туры яр башыннан йөгереп килеп, зәңгәр тирәнлеккә сикерәсең...* И.Юзеев. *Нәкъ каршысында, төпсез тирәнлектә җемелдәгән эре бер саргылт йолдызга карап, ул шулай ятты да ятты*. З.Мифтахов

3) Тирән булу; тирән булу дәрәҗәсе. *Егет казуыннан туктады. Чокырының тирәнлеге күкрәгенә җитеп килә иде*. А.Хәлим

4) *күч*. Тирәндә урнашкан урын яки нокта. *Сагаю да бар иде ул күз тирәнлегендә, тик сукыр мәхәббәт аны күрмәде, абайламады...* А.Гыйләҗев // Нәрсәнең дә булса иң эчендә яки бик арткы планда урнашкан урын яки нокта. *Бакчаның чиксез тирәнлегенә күмелеп югалган шомырт куаклары арасыннан кызлар көлүе ишетелде*. М.Әмир. *Кайдадыр еракта, урман тирәнлегендә күке кычкырып куйгандай булды...* М.Хәсәнов

5) *күч*. Уй-хисләрнең тирәнгә яшерелгән, иң яшерен, иң нечкә ягы; төпкел. *Бер Ленаның гына тормышы челпәрәмә килмәде ич бу кара вакыйгадан соң, безнең дә – аның дусларының да – күңел тирәнлегендә башкаларга ышану тетрәде, гомер онытылмаслык җәрәхәт эзләре сызылып калды*. А.Гыйләҗев. *Баштарак ул моны аңламады, тегә чакта майор әйткән шик тулы сүзләрнең мәгънәсенә тора торып кына бөтен тирәнлеге белән төшенде*. М.Маликова

**ТИРӘННӘН** *рәв. к.* **тирәнтен**. *Күмәк хуҗалыкның ул чактагы рәисе Сабира апа хатынның кайгысын тирәннән аңласа да, мондый җаваплылыкны үз өстенә ала алмады*. А.Хәлим

◊ **Тирәннән йөзү** *к.* **тирән йөзү**. *Әгәр бала гореф-гадәтләрен, тарихын белми икән, аның иҗат итәргә сәләте булса да, ул тирәннән йөзә алмаячак*. Тигез гомер итегез! **Тирәннән сукалау** *к.* **тирән йөзү**. *Таһирыбыз рәсем сәнгате өлкәсендә шактый тирәннән сукалый булып чыкты бит*. А.Хәсәнов

**ТИРӘНТЕН** *рәв.* 1) Эчтән үк

2) Ерактан ук. *Әллә кайлардан тирәнтен гөрләп килеп күк күкри*. Ш.Камал

3) Тирән итеп. *Таҗи абзый тирәнтен сулап куйды да кызулыгын тыя төшкәндәйрәк итеп әйтте: – Егылып та китәрсең шул...* Ш.Маннур. *Басуларны өч ел – өстән генә, бер ел тирәнтен сөрәбез*. Кызыл таң

4) *күч*. Ныклап өйрәнеп, белеп, аңлап, төрле нечкәлекләренә игътибар итеп. *Ул аны буеннан-буена, борынгы дәверләреннән башлап, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Русия дәүләте составындагы чорларны да кертеп, XIX гасырга кадәрге чорларына кадәр колачлап ала, әтрафлы һәм тирәнтен тикшерә*. М.Хәсәнов

5) *күч*. Тирән мәгънә белән, уйлап, фикерләп. *Рәдиф Гаташ – язма һәм сөйләмә тел байлыгын, шигъри казанышларны тирәнтен тоеп, белеп язучы әдип*. Х.Миңнегулов. *Ул [Гөлсем Сөләйманова] халыкның моңын гына түгел, психологиясен, көнкүрешен, тарихын, нинди халык булуын, кыскасы, аның эчке дөньясын тирәнтен сизеп, аңлап, кичереп җырлый*. А.Арсланов

◊ **Тирәнтен йөзү** *к.* **тирән йөзү**. *Әмма бездә, гомумән Россиядә, җыр сәнгатендә тирәнтен йөзә торган тәнкыйтьчеләр юк*. Ватаным Татарстан. *Кешедән эш таләп итү өчен, җитәкченең үзенә әлеге тармакта тирәнтен йөзү кирәк*. Хезмәт. **Тирәнтен сөрү** *к.* **тирән йөзү**. *Берәр язучының портретын эшләргә яки аерым бер әсәрен иллюстрацияләргә алына икән, Тавил инде ул авторның бөтен иҗатын ныклап өйрәнмичә туктамый. Фәкать шулай тирәнтен сөргәндә генә әдипнең образын тулаем күзалларга мөмкин, дигән фикердә бу рәссам*. К.Миңлебаев

**ТИРӘСЕНДӘ** *бәйл.* 1) *к.* **тирәли 1.** *Әнә күрәсезме, кара гына, шома гына бер эшче корт өй тирәсендә әйләнә: өйгә керергә исәбе, белә ул кая яшерелгән бал кисмәге*. А.Алиш. *Бу китабында Птолемей планеталарның хәрәкәтсез Җир тирәсендә әйләнеп йөрүе турындагы тәгълиматын бәян итә*. А.Тимергалин

2) Чама белән, якынча. *Миңа ике-өч яшьләр тирәсендә Галимҗан абыйларга кунакка бардык*. А.Хәсәнов

**ТИРӘСЕНДӘГЕ** *бәйл.* Чама белән билгеле күләм, предмет, күренеш һ.б.ш.га караган. *Куе кара мыеклы, утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге ул агай Арчадан Усы өяз комитеты тарафыннан биреп җибәрелгән белешмә-характеристиканы бик җентекләп укып чыкты ---*. В.Нуруллин. *Бакчадан ун яшьләр тирәсендәге малай яныбызга йөгереп килде*. А.Нәҗми

**ТИРӘЧ** *и.* Түгәрәк яки овал кыса. *Күзлек тирәче*

**ТИРӘЧЛЕ** *с.* Түгәрәк яки овал кысалы. *Биек түбәле матур хәрби фуражкасын яңгырга чылатмас өчен башлыгын да күтәргән – Алиш аны кара тирәчле күзлегеннән таныды*. Ш.Маннур. *Зур кесәле яшел күлмәк, --- башына киң тирәчле сомбреро кигән, җиңел гәүдәле, чәчрәп торган шушы егет игътибарымны җәлеп итте*. Г.Гомәр

**ТИРӘ́-ЮНЬ** *җый. и.* Билгеле бер ноктага, төбәккә якын, күренеп торган урыннар, якын әйләнә-тирә. *Ул УАЗигы белән урман эченә керде. Тирә-юньнән төрле үсемлек, чәчәк, черегән агач исләре килә*. Р.Сәгъди. *Мөсәвил падишаһ --- хатынын диңгез яры буйларыннан, тирә-юньнән эзләтте*. Ф.Яхин

**ТИРӘ́-ЯК** *җый. и.* **1.** 1) Билгеле бер ноктаны, төбәкне һәр яктан әйләндереп алган тирәлек, тирә-юнь. *Кояшлы якты көн, тирә-якта гөлчәчәкләр исе аңкый, аларның йомарлам-йомарлам алсу, кызыл чәчәкләре урамнарга ямь өстенә ямь бирә*. Т.Әйди. *Күлнең тирә-ягы камышлы саз, ә көньяк яры коры һәм калку күренә иде*. И.Хуҗин

2) Як, төбәк, бер тирәдәрәк булган торак пунктлар, объектлар җыелмасы. *Заманында өяз үзәге булып торган, зур базарлары, мәктәпләре, дүрт-биш мәчете, укымышлы, галим кешеләре белән бөтен тирә-якка дан казанган бу татар авылы ничек барлыкка килгән*

*соң --- ?* Ф.Бәйрәмова. *Данлыклы курайчы ул, тирә-якта берәү генә!* Г.Якупова

**2.** *с. мәгъ.* Әйләнә-тирәдәге, тирәюньдәге. *Тирә-як урамнарны сырып алган халык диңгезе, --- ни булыр дип сабырсызланып көткән минутта, кинәт мәдрәсәнең зур ишекләре ачылып китә.* Г.Ибраһимов. *Теге өч ирнең икесе – балта остасы, берсе – мич чыгаручы, гомерләрен күбрәк тирә-як районнарда, хәтта чит өлкәләргә чыгып та эшләп үткәрүчеләр икән.* В.Нуруллин

**ТИРӘ́-ЯН** *җый. и.* Берәр нәрсәнең як-яклары; тирә-як. *Монда --- юлның ике ягына рәт-рәт итеп пөхтәләп, ныклы күз астында утыртылган яшьтәш каеннар бөреләрен ачып, дөньяга меңмиллионлаган күз белән карап, тирә-яннарына сокланып чайкалалар иде.* А.Гыйләҗев. *Җәләй карт үзен гадәттән тыш җитди, тирә-янындагы эш һәм хәрәкәтләргә бөтенләй игътибарсыз тота.* Н.Яһүдин

**ТИРБӘЛДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тирбәлү**. **---** *ул берни күрми, керфекләрен тирбәлдереп, күз алмасына килеп бәялгән яшь бөртеген әледән-әле кысып чыгара.* А.Вергазов. *Кыйбла яктан җиләс җилләр исә, Тирбәлдереп яшел үләнне.* Р.Маннапов

**ТИРБӘЛЕШ** *и. к.* **тирбәнеш**. *Әти кеше берара аның сылу гәүдәсенә, нәфис, килешле тирбәлешләр ясап бөгелгән тылсымлы кулларына сокланып карап торды...* Н.Гыйматдинова. *Үз тавышлары, үз моңнары, үз гамьнәре, үз стильләре белән шигърияткә килгән яшьләр бер ритм, бер тирбәлеш, бер юнәлештә салмак кына агып яткан әдәби агымны төрле юнәлешләргә борып җибәрделәр.* Р.Фәйзуллин

**ТИРБӘЛҮ** *ф.* 1) Йомшак кына селкенү, салмак кына чайкалу. *Сабит, урылмаган кыр өстендә тирбәлгән серле рәшәне, җылы дулкыннарда тибрәлгән тургайларны күзәткән булып, читкәрәк китте.* А.Гыйләҗев. *Бу көй, җил уңаена җай гына тирбәлгән юкәләрнең ябалдашларына уралып, бер урында очынып-сихерләнеп торды ---.* А.Вергазов

2) Алга һәм артка, бер яктан икенче якка яки өстән аска талгын ритмда хәрәкәт итү. *Бәйләнгән мичкәләр кавыч кебек аска-өскә тирбәлделәр.* А.Тимергалин. *Бәшир углы Гомәр дигән малай шунда дөньяга аваз салган, шунда аның бишеге тирбәлгән.* М.Вәлиев

**Тирбәлә башлау** Тирбәлергә тотыну. *Ләкин, кире авылга кайткан чакта, күңеле бөтенләй икенче нәрсә өмет итеп тирбәлә башлады.* Н.Фәттах. *Шул вакыт кай урындадыр, тирәндә, башта сизелер-сизелмәс кенә, аннан бөтен тәнгә-җанга таралып, таныш бер көй тирбәлә башлады.* И.Юзеев

**Тирбәлә тору** Бернигә карамастан тирбәлүне дәвам итү. *Шулай тирбәлә торгач, ул бишеге-ние белән әнкәсенең кулыннан ычкынып китә дә... галәм киңлегендә очып йөри башлый.* Г.Гыйльманов

**Тирбәлеп алу** Бераз гына тирбәлү. *Җаббаровның яңак сөякләре тирбәлеп алды.* А.Вергазов. *Дала тирбәлеп алды.* А.Хәлим

**Тирбәлеп кую** Бер тапкыр тирбәлү хәрәкәте ясау. *Туктаров ике кулын кесәләренә тыккан хәлдә тирбәлеп куйды.* А.Хәсәнов. *Аннары боз кисәге дә урыныннан кубып, чак кына калыкты да бәке өстендә тирбәлеп куйды.* М.Хәсәнов

**Тирбәлеп тору** Әле, хәзер тирбәлү; һәрвакыт, бертуктаусыз тирбәлү. *Марлядан ясалган юка пәрдә әкрен генә тирбәлеп тора.* Г.Әпсәләмов. *Причалның нык такталарыннан тирбәлеп торган палубага барып төшкәч, чайкалып егыла язды, аягына чак басып калды.* М.Маликова

**ТИРБӘЛЧЕК** *с.* **1.** Тирбәлә торган. *Тирбәлчек ботак*

**2.** *и. мәгъ. к.* **тирбәнчек 2.** *Тирбәлчектә бала тирбәнә*

**ТИРБӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **тирбәнү**. *Вагон тәгәрмәчләре дә, үч иткәндәй, «бәлли-бәлли итәр бу» дигән сыман тирбәндереп баралар, башны түбән идерәләр.* Г.Кутуй

**ТИРБӘНЕШ** *и.* 1) Тирбәнү хәрәкәте. *Эластик материал тирбәнешкә гаять чыдам, ул теләсә нинди корычтан да өстенрәк, нәтиҗәдә очу аппаратының эксплуатация вакытын шактый озынайтырга мөмкинлек туа.* Р.Ибраһимов. *Белгечләр, Себернең көньяк районнарында җир астында тирбәнешләр әле тагын ике-өч ай дәвам итәр, дип фаразлыйлар.* Татарстан яшьләре

2) Алмашучанлык, үзгәреп торучанлык; тотрыксызлык. *Үзенең күп кенә җырларында ул --- кеше күңелендәге тирбәнешләрне музыка теленә күчереп аңлата.* Р.Низамиев. *Температураның сезонга карап һәм тәүлек эчендә тирбәнеше зур түгел.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТИРБӘНҮ** *ф.* 1) *к.* **тирбәлү**. *Талдан талга күчеп куышып йөрдек, Ботакларга басып тирбәндек, Күпме уен, күпме җыр өйрәндек – Бар да, бар да сагынып сөйләрлек.* М.Җәлил

2) *күч.* Даими булмау, үзгәреп тору. *Базар бәяләре тирбәнү*

**Тирбәнә башлау** Тирбәнергә тотыну. *Ул менә бөтенләй онытылды. Йомшак кына саллана торган көймәгә утырган кеше кебек, китапның язылу музыкасында тирбәнә башлады.* Г.Исхакый. *Кызчык керә-керешкә бүлмәне бер әйләнеп, әйберләргә кагылып, бөтерелеп алды, диванга үрмәләп менде дә тирбәнә башлады.* Ш.Галиев

**Тирбәнеп алу** Бераз гына тирбәнү. *Машина йомшак кына төртелеп тукталды да алга таба бер тирбәнеп алды.* М.Мәһдиев. *Гөл яфраклары тирбәнеп ала.* Р.Бәшәр

**Тирбәнеп карау** Тикшерү-белү максаты белән тирбәнү. **---** *тайга, тау камышларыннан шыгырдавыклы урындыклар, бала коляскалары үрергә Миңнулланың осталыгы җитмәс дисеңмени? Утрау балалары ул үргән коляскаларда да тирбәнеп карасын.* Ә.Маликов

**Тирбәнеп кую** Бер тапкыр тирбәнү хәрәкәте ясау. *Әтәч башын кыңгыр салган да, ут кызыл кикриге һәм алкалары селкенеп-тирбәнеп куя.* Р.Низамиев. *--- иртәнге йомшак җилнең исеп алуыннан, зәңгәр кыңгырау чәчәкләре, бер-беренә хәерле иртә теләгәндәй, тирбәнеп куялар.* Г.Васыйлова

**Тирбәнеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз тирбәнү; әле, хәзерге моментта тирбәнү. *Давыл башланганга ике тәүлек тулып өченчегә киткәч, кич белән җил басылган, диңгез шактый кутә-*

*релеп чайкалса да, күбекләр пошкырмый, йомшак кына тирбәнеп тора иде.* Ш.Камал. *Уйсурак җырлардән әле эрегән кар исе аңкый, үрләр өстендә җиңел рәшә тирбәнеп тора.* Г.Әпсәләмов

**ТИРБӘНЧЕК** *с.* **1.** Тирбәлеп утырырга җайланган. *Атларда булыр җиз ыңгырчак, Тирбәнчеккәй арба бик йомшак.* Җыр. *Дачага җиһаз дисеңме? Боер гына! Камыш урындыклар, тирбәнчек көрси.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тирбәнеп утыру яки яту өчен җайланган урындык. *Тирбәнчеккә утырып ял итү*

2) Утырып яки басып атыну өчен, баганага һ.б. асылган җайланма, таган. *Чәчәкләр әйтерсең лә тирбәнчектә атыналар.* Безнең гәҗит

**ТИРБӘТМӘ** *и.* Рессор, сиртмә. *Повозканың --- куәтле тирбәтмәләре, чокыр-чакырларга туры килгәндә дә тигез вә салмак кына тирбәтеп, рәхәт ялкауландыра.* Ф.Әмирхан. *Галләм абзый аптырап калды. Алар монда муеннан дигәндәй майга, пычракка батып машина рәтли, тирбәтмә алыштыра, ә ул, берни булмагандай, гармун тарта.* Р.Кәрами

**ТИРБӘТМӘЛЕ** *с.* Тирбәтмәсе булган. *Ишек төпләрендә тирбәтмәле арбада бала йоклатучы ике хатын һәм бер-берсе белән гәпләшүдән тәм табып, шушындагы утыргычта көннәрен уздыручы биш-алты карчык кына.* Н.Әхмәдиев

**ТИРБӘТҮ** *ф.* 1) Йомшак кына итеп яки ритм белән селкетү, чайкалдыру. *Пароходны уйнап кына тирбәткән кыргый диңгез, --- тора-бара минем кәефемне тәмам яхшыртты.* Ә.Еники. *Аннан Ул Әлфияне кызык иткән: Алдына алып тирбәткән, Әлфия йоклап киткән.* М.Шабаев

2) *к.* **тибрәтү** (*2 мәгъ.*). *Кичке җил дәү әрекмән яфракларын тирбәтте, агачтан агачка күчә-күчә, төн килде, сандугач килмәде.* А.Гыйләҗев. *Чия чәчәге таҗында Өч бал кортын тирбәтте.* Р.Зәйдулла

**Тирбәтә башлау** Тибрәтергә тотыну. *Ильяс, күзләрен кысып, кулын алга сузды да, диңгез кебек җәелеп яткан колхоз кырларында тук башаклар чайкалуын күрсәткәндәй, җай гына тибрәтә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Исрафилов берәр сүз әйтергә тел тибрәтә башласа, йөз сүз белән моның авызын томалады.* Ф.Яруллин

**Тирбәтеп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә тирбәтү. *Аннары пычкысын тибрәтеп алды, Асия кулындагы гармунга карап мут кына елмайды.* Г.Әпсәләмов. *Бу юлы да күз кабакларын челт-челт тибрәтеп алды да тезеп китте: – Менә хәзер лётчик Марат абый үзенең ярапланы белән, теге вакыттагы кебек, безнең Үзәнле өстенә килеп чыкты, ди.* Н.Хәсәнов

**Тирбәтеп җибәрү** Кинәт кенә тирбәтү. *Һәм ул пычкының бер башын скрипка кебек ияк астына кыстырып, икенчесеннән шундый тибрәтеп җибәрде: гади пычкы сандугач кебек сайрый башламасынмы!* Г.Әпсәләмов. *Йосыф, гомер иткән карчыгыннан башка, үз янына кемне дә булса кабул итәрлек хәлдә түгел иде. Әмма Габделбәр авызыннан чыккан Йөзембикә исеме аның күңел кылларын тибрәтеп җибәрде.* Г.Нурулла

**Тирбәтеп карау** Тикшерү-белү максаты белән тирбәтү. *Аның бердән үрелгән толымын учына алып, үлчәргә теләгәндәй тирбәтеп карады.* М.Галиев. *[Бишек] чөйлегеп китәрлек түгелме дип, кат-кат тирбәтеп карады, каешларны бер кыскартты, бер озайтты.* Ф.Әмәк

**Тирбәтеп тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында тирбәтү. *Бу җыенда катнашучылар арасында балаларын арбада тибрәтеп торучылар шактый иде.* А.Кормаш

**ТИРБӘ́Ү** *ф. сир.* 1) *к.* **тирбәтү**. *Каштан чәчәк ата, --- Тәлгәшләрен җилләр тирби.* Ә.Фәйзи

2) *күч. к.* **тибрәтү** (*2 мәгъ.*). *Вагон көпчәгенең озын җыры Кай төшендер тирби күңелнең.* Ш.Маннур

**ТИРГӘЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **тиргәү**. *Тора-бара бер хакыйкатьне аңлады: планны үтәсәң – син кеше, планны үтәмәсәң – кеше түгел. Беренче очракта сиңа кадер-хөрмәт, дан, мактау, икенче очракта тукмалу, тиргәлү, хурлану.* Ф.Садриев. *Әрләнеп, тиргәлеп, эт итеп сүгеп чыгаруга әзер булып кергән Әнисә югалып кала.* Т.Галиуллин

**Тиргәлә килү** Күптәннән, алдан ук, кат-кат тиргәлү. *Байтак вакытлар тиргәлә килгән әдәби тәнкыйть соңгы елларда тәмам югалды. Басылып чыккан әсәрләр үзләренең тиешле бәясен алмый, алар хакында җанлы әңгәмә, фикер алышу юк.* Казан утлары

**Тиргәлә тору** Даими рәвештә, һәрвакыт тиргәлү; кат-кат тиргәлү. *Әнә шулай каргала-тиргәлә торгач, Таһир түзмәде: балдызы имтиханга әзерләнеп яткан бүлмәгә килеп керде.* Н.Акмал

**Тиргәлеп тору** Әле, хәзер тиргәлү; даими рәвештә, һәрвакыт тиргәлү. *Кыскасы, гел тиргәлеп торган ЖКХ да, юлчылар да шушы районда яшәүчеләрнең яшәеш шартларын күпмедер яхшыртмакчылар инде.* Шәһри Казан

**ТИРГӘНҮ** *ф.* Нәрсәдәндер канәгать булмыйча, үз-үзеңне яки кемне дә булса үзалдыңа тиргәү. *Шәяхмәт бүген --- атына сукмый, тиргәнми.* Ә.Фәйзи. *Бу ни булып чыга инде? Киңәш юк, сөйләшү юк, тот та өйлән, имеш. Эченнән генә шулай тиргәнде Гафур, ләкин кайтарып сүз әйтмәде.* Җ.Рәхимов

**Тиргәнә башлау** Тиргәнергә тотыну. *– Менә чиртешле уйнап утырам. Чоланга чыгарга туры килде: өйдә уйнасам, абыең тиргәнә башлый. Син ачуланма инде миңа, – диде карчык.* М.Галәү. *Ишек ачып керер хәл юк: «Урамда йөргән аяк киемеңне ник өйгә сөйрисең?» – дип, әни тиргәнә башлый.* Л.Гыймадиева

**Тиргәнеп алу** Бераз тиргәнү. *Караңгы коридордан үткәндә тиргәнеп алдым.* Р.Кәрами. *Шакирә эченнән генә тиргәнеп алды: – Кысыр хәсрәт!* Р.Габделхакова

**Тиргәнеп йөрү** Бертуктаусыз тиргәнү. *Рәмзия моңа бик нык өзгәләнә. Ләкин орылып-бәрелеп тиргәнеп йөрми.* Г.Гыйльманов. *Урам буйлап бәрелеп-сугылып, тиргәнеп йөрде дә, кайтып, баш төзәтеп, бүрәнәләр арасына бөкләнеп төшеп йоклап китте...* Кәеф ничек?

**Тиргәнеп кую** Кинәт бер мәртәбә тиргәнү. *Сидоров, запас маскхалат алмавы өчен үз-үзенә ачуланып, тиргәнеп*

*куйды.* Г.Әпсәләмов. – *Шайтан! – дип тиргәнеп куйды Солтанъяр.* З.Мурсиев

**Тиргәнеп тору** Хәзер, шушы моментта яки даими рәвештә тиргәнү. *Директор апа ләң-ләң итеп тиргәнеп торды.* Л.Гыймадиева. *Әйе, мондый хатынның көн саен өйдә тавыш чыгаруына, --- гомере буена ашау турында гына сөйләнеп-тиргәнеп торуына гаҗәпләнергә урын калмый.* М.Яһудин

**ТИРГӘҮ** *ф.* Кемне дә булса ачулану, сүгү, хурлау, әрләү. *Ә безне, качакларны, кочак җәеп каршыламадылар. Мәктәптә дә, өйдә дә, урамда да тиргәделәр.* И.Юзеев. *Әнә бит әнкәсе тиргәгән саен: «Йөрмә шул тауга, эчендәге рухлары чыгып, сихерләп дивана ясарлар», – дип тирги.* Г.Гыйльманов

**Тиргәп алу** Аз гына вакыт, бераз гына тиргәү. *Фәрдәнә ахыр чиктә күңеленнән улы өчен Хәбирне тиргәп алган чаклары да була.* Х.Камалов. *Шундук: «Нәрсә җебеп төштең?» – дип, эченнән үз-үзен тиргәп алды.* М.Маликова

**Тиргәп бетерү** Бик каты тиргәү. *Әзмәвердәй егет, Нургалине утыртуы өчен, үзен ничек кенә тиргәп бетермәде.* Н.Хәсәнов. *Сез мине тиргәп бетергәнсездер инде.* М.Вәлиев

**Тиргәп йөрү** Кабат-кабат тиргәү, озак вакыт тиргәү. *«Аерылгач та әле белерсең» дигән сүзләремне хәтерлимсең? Юкса һаман тиргәп йөримсең?* А.Алиш. *Корреспондент китеп баргач та, тынычланып җитә алмыйча, күңеленнән аны тиргәп йөрде.* Г.Ахунов

**Тиргәп ташлау** *сөйл.* Кызып китеп каты гына тиргәү. *Дуслары Фәниярга ялгыз калырга да, эшсез ятарга да ирек бирмәделәр. Таләп иттеләр, ялкаулана башласа, тиргәп ташладылар.* Ф.Яруллин. *Тракторчы Имай шунда, миңа иске трактор бирдең дип, Шаязны аты-юлы белән тиргәп ташлады.* Ф.Садриев

**Тиргәп тору** Хәзер, шушы моментта яки даими рәвештә тиргәү. *Ачык ишектә Бәһиҗә түтәй ирен тиргәп тора иде: – Ничә әйттем мин сиңа, шуны берәр кая олактыр, дип!* М.Маликова. *Әбисен бик яхшы аңлый малай: юньсез булгач, Рөстәмнең әтисен гел тиргәп тора ул.* Л.Ихсанова

**Тирги башлау** Тиргәргә тотыну. --- *Сөмбел Якупка якын килде һәм күзләрендә чакматаш чаткылары чатнатып тирги башлады.* А.Хәлим. *Шулай газапланып, анда кагылып, монда сугылып йөргәндә, Рөстәм үзе килеп кулымны тотты. Үземне тыя алмыйча, аны пыр туздырып тирги башладым.* Л.Ихсанова

**ТИРГӘШ** *и.* 1) Үзара тиргәшү күренеше. *Мин инде хәзер мораль уку, ачуланыш-акланыш, тиргәш китәр дип көткән идем, алай булып чыкмады.* Р.Миңнуллин. *Монда Апрай аркасын ачып ята, тегендә тиргәш, кычкырыш дәвам итә, көче җитмәгәннәр елашалар иде.* Г.Гыйльманов

2) Ачулану, әрләү, орышу сүзләре. *Бөтен ишегалды тавыш, талаш, тиргәш белән тулды.* М.Хәсәнов. *Әмма ерак китә алмады Вахит, зәһәр тиргәш, каргыш тавышлары ишетеп, артына борылып карады.* Г.Гыйльманов

**ТИРГӘШҮ** *ф.* Бер-берең белән үзара сүзгә килү, ызгышу, талашу, әрләшү. *Аның теленә егылып үләрсең. Хәер, монда башкалар да шундый: тиргәшәләр, талашалар.* Н.Фәттах. *Ул көнне күршеләр бик озак тиргәштеләр...* Р.Ахунова

**Тиргәшә башлау** Тиргәшергә тотыну. --- *мин кайтканны белгән килеш, берничә көн буе телефоннан да шалтыратмагач, хәтта ачу кузгалды: беренче сүз итеп тиргәшә башлармын кебек иде.* Ә.Баян. *Кичен Рәсим абый эштән кайтты да нәрсәгәдер ачуланып тиргәшә башлады.* Р.Ахунова

**Тиргәшә язу** Чак кына тиргәшмичә калу. *Директорга кереп тиргәшә язсам да: «Әгәр без гел үз теләгәнебезне генә эшләп йөрсәк, тормышның кызыгы калмас иде», – дигән фәлсәфи нәтиҗә генә ишеттем.* Ә.Баян

**Тиргәшеп алу** Берара, кыска вакыт яки бер тапкыр тиргәшү. *Безнең малай чактагы кебек алар да качышлы уйныйлар, кычкыралар, бер-берсен хәрәмләшүдә гаепләп, чәте-чәте тиргәшеп алалар.* Н.Фәттах. *Андый тормыш та көнләшерлек түгелдер: китсә ялгыз, кайтса ялгыз, бер рәхәтләнеп тиргәшеп алырлык кешең дә булмагач янында.* К.Кара

**Тиргәшеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, төрле урыннарда, берөзлексез тиргәшү. *Нинди чыдамлык, ди, ул? Чыдам булган кеше секретарь белән тиргәшеп йөримени, авыру хатын белән әйтешәмени?* Н.Фәттах

**Тиргәшеп китү** Кинәттән яки көтмәстән тиргәшә башлау, ниндидер сәбәп белән тиргәшергә тотыну. *Безнең бер компьютер, ике планшет, ике ноутбук бар, әмма бу гына җитми, балаларның шул компьютер аркасында тиргәшеп китүләре дә бик мөмкин, шуңа да кызларның зурларына телефон алдык.* Кызыл таң. *Хәтсез еллар гаилә булып яшәгән, шушы никахта өч бала тәрбияләгән урта яшьләрдәге ир белән хатын юктан гына тиргәшеп китә.* Өмет

**Тиргәшеп тору** Гел, даими тиргәшү; хәзерге моментта тиргәшү. – *Шуның өчен тагын берне күтәреп җибәр әле, әтәй, – диде. – Хатын-кыз тиргәшә торсын. Тиргәшмәсә, ул хатын-кыз да булмай.* Н.Фәттах

**ТИРГӘШЧЕ** *и.* Тиргәшүчән, тиргәшергә гадәтләнгән, тиргәшергә оста кеше. *Тиргәшчегә тыңлашма, талашчыга таңланма.* Мәкаль

**ТИРЕ** I *и.* **1.** 1) Организмны каплап торган, тышкы тәэсирләргә чыдамлы тән тышчасы. *Бермәлне балалар йортында йогышлы тире авыруы – кырчын тарала.* А.Тимергалин. *Аркасының яртысы диярлек зәңгәр, кызыл тире белән капланган: өзгәләнгән яра эзе калган.* З.Зәйнуллин

2) Үтерелгән, суелган хайваннан тунап алынган тышча, күрек яки күн итеп эшкәртү өчен чимал. *Тире эшкәртү, сабын кайнату мануфактуралары, нигездә, йомышлы татарлар кулында булган.* М.Мәһдиев. *Йомшак болан тиресе өстенә ике шешә спирт чыгарып куйгач та, хуҗалар «алмыйбыз» дип баш тартып маташтылар.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тышчадан тегелгән, эшләнгән. *Өстенә кыршылган тире тун, башына колакчын малахай кигән карт шунда гына икән ---.* А.Вер-

газов. *Тирә-якны тире барабан тавышлары баса.* А.Хәлим

◊ **Тире белән сөяккә калу** Бик ябыгу. *Ачлыктан, чамасыз газаплардан интеккән, тире белән сөякләре генә калган бик ябык, хәлсез кешеләр --- иреккә чыктылар.* А.Шамов. **Тире дә (белән) сөяк кенә** Үтә ябык, арык. **Тире җыеп күн эшлим** «Нишлисең?» дигән сорауга каршы шаяртып бирелә торган җавап. *– Теләгән кеше нишли, беләсеңме? – Тире җыеп күн эшли.* З.Мурсиев. *– Әнәс, контрабандистлар нишли? – дип сорыйм. – Тире җыеп күн эшли!* Р.Габделхакова. **Тире иләп күн эшлим** *к.* **тире җыеп күн эшлим**. *– Кызлар нишли анда, нигә бик озак! – дип, түр якка ишеттерде Җик Мәргән. – Тире иләп күн эшлибез! – дип җавап бирде аңа Зәйтүнә.* М.Хәбибуллин. **Тиресе калын** Һәртөрле шелтә, тәнкыйть сүзләренә исе китми торган. *Ләкин бу өшү-сызлану тыштан караганда күренми, шунлыктан мастерскойда Мәрьямнең көенечләре хакында җиңелчә көлемсерәп сөйлиләр: «Безнең Мәрьям бирешми, тиресе калын аның», – диләр.* М.Маликова. *Авыл кешесенең тиресе калын булса да, күңеле нечкә аның.* Р.Вәлиев. **Тиресенә сыеша алмау** *к.* **тиресенә сыймау**. *Җәүһәргә ишелеп төшкән бу бәхеттән Илсөяр тиресенә сыеша алмас хәлгә килде.* Ф.Яруллин. *Ул һаман, тиресенә сыеша алмас дәрәҗәгә җитеп, әтиемнән акча таләп итә.* Э.Шәрифуллина. **Тиресенә сыймас булу** *к.* **тиресенә сыймау**. **Тиресенә сыймау** 1) Бик каты ярсып ачулану. *Болай да әле ул ачуыннан тиресенә сыя алмыйча йөри.* Г.Камал. *Галимҗан өчен әтисе, үз тиресенә сыя алмаган арыслан шикелле котырынып, аның өстенә йодрыкларын төйнәп ташланды ---.* С.Поварисов; 2) Артык симерү, юанаю; 3) Бик нык кәпрәю, масаю. **Тиресеннән чыгарга җитешү** 1) *к.* **тиресенә сыймау**; 2) *к.* **тиресеннән чыгу** (*2 мәгъ.*). *Егетләр, --- тирeләреннән чыгарга җитешеп, кунакка ярарга, аның күңелен табарга тырышалар.* Ш.Бикчурин. **Тиресеннән чыгарлык булу** 1) *к.* **тиресенә сыймау**. *Фабарисовка мәдрәсә турында Мәскәүдән дә гел тамызып, кыздырып тордылар ---. Шуңа күрә Фабарисов та тиресеннән чыгарлык булып тырышты: мәдрәсә өстенә бәла-казаларны, борчу-проблемаларны өеп кенә торды.* Ф.Бәйрәмова; 2) *к.* **тиресеннән чыгу** (*2 мәгъ.*). **Тиресеннән чыгардай булу** 1) *к.* **тиресенә сыймау**. *Сарычев үзенең аппараты белән, тиресеннән чыгардай булып, халык җыя башлады.* Ә.Салах; 2) *к.* **тиресеннән чыгу** (*2 мәгъ.*). *Әлбәттә, аның бу тырышлыгын тиз күреп алдылар. Тиресеннән чыгардай булып тырышкан кеше күләгәдә калмый ул, андыйларны бәһали беләләр бездә.* Р.Зәйдулла. **Тиресеннән чыга язу** 1) *к.* **тиресенә сыймау**. *Байбикәнең Арча станциясеннән каядыр озату өчен төяткән ике вагон тактасын, ниндидер сәбәпләр аркасында --- поездга такмаулары турында хәбәр китерделәр. Әби патша тиресеннән чыга язды.* М.Хәсәнов; 2) *к.* **тиресеннән чыгу** (*2 мәгъ.*). **Тиресеннән чыгу** 1) *к.* **тиресенә сыймау**. *Парторг чагында йорт саен кереп, аракы таптырып, тиресеннән чыгып Алла сүккән атеист Җәмшык, мулла булып кайткач, үтә диндар булып китте.* Р.Батулла; 2) Берәр максатка ирешү яки нинди дә булса эшне башкару өчен, бик күп көч кую. *Гаяров, якын дустының якты истәлеге өчен, тиресеннән чыгып, дөньяның астын өскә китерәчәк.* Т.Галиуллин. *Ә Нәсих тапканга гына тормыш алып баруларны ык авырлашканга күрә, Нәгыймә апага, кем әйткәндәй, тиресеннән чыгып йорт-җирдә бөтерелергә туры килде.* Ш.Алпар. **Тиресен тунату** *к.* **тиресен тунау**. *Сельсовет кооперация эшен карамый гына түгел, белә торып авылның тиресен туната.* Т.Гыйззәт. **Тиресен тунау** 1) Кыйнау. *Лагутченконың да ике кат тиресен тунарга кирәк!* Ә.Галиев; 2) Бик каты эксплуатацияләү, изү. *– Ябай халыкның тиресен тунар өчен, түрә-бояр кырыкмаса кырык фәрман уйлап табар инде, – дип, аны башка крәстияннәр дә эләктереп алды.* В.Имамов. **Тиресе сөягенә ябышу** *к.* **тире белән сөяккә калу**. *Тәнендә карга чукырлык та ите юк. Тиресе сөягенә ябышкан.* Халык афоризмнары. *Халыкның тиресе сөягенә ябышкан.* Ш.Галиев. **Тиресе юка** Тиз хәтере кала, тиз үпкәли торган, үпкәчел

**ТИРЕ** II *и. фр.* Горизонталь озын сызык рәвешендәге тыныш билгесе. *Тире урынына дефис кую гадәткә кереп китте инде*

**ТИРЕАШАР** *и. зоол.* Катыканатлылар семьялыгыннан тиредән, мехтан эшләнгән әйберләрне, ысланган, какланган ит, кипкән җиләк-җимешләрне зарарлый торган корткыч коңгыз; *русчасы:* **кожеед**. *Зарарланган хайваннарның бернинди кыйммәте калмый. Коллекция корткычлары аз түгел. Иң куркынычлары тиреашар коңгызлар семьялыгыннан: музей тиреашары, берничә төр келәм тиреашары һ.б.* Яшь натуралистларга

**ТИРЕС** *и.* **1.** 1) Терлекнең салам һәм печән калдыклары белән аралашкан тизәге (ашлама сыйфатында һәм кизәк сугу өчен файдаланыла). *Сугыш вакытында басу түренә кул чанасы белән без тирес чыгарганда, Чулак Абдул тире иләп акча сугып ятты.* М.Мәһдиев. *Сәгыйдә, нәрсәдәндер өркенгән кыяфәттә, сәнәгенә таянып, кардан чыккан саламлы тирес өеме өстендә басып калган.* Н.Хәсәнов

2) Нәрсәнең дә булса кире ягы, арткы, эчке, тискәре ягы

3) *диал.* Төньяк. *Тирестән искән җил*

**2.** *с. мәгъ. диал.* 1) Кире, сул; арт. *Тискәре тирес ягы белән туа.* Мәкаль

2) Кирегә юнәлгән, кирегә табан булган. *Тирес юл*

3) Төньяктан искән (җил тур.)

4) Юл уңаенда, юл өстендә булмаган, читтәге, еректагы. *Бу авыл тиресрәк якта*

5) *күч.* Тискәре холыклы; явыз, яман. *Тирес кеше дә телдәр, тиген кеше дә телдәр.* Мәкаль

◊ **Тирес яктан карау** Өнәмәү, яратып бетермәү, хупламау. *Без әүвәлдән үк аларга тирес яктан карыйдыр идек, моннан ары һәм шулай карармыз һәм карарга тиешбез.* Г.Исхакый

**ТИРЕ́С БАКАСЫ** *и. зоол. к.* **гөберле бака**. *Идән астында --- берничә бака да бар иде бугай. Тирес бакалары.* Ш.Камал

**ТИРЕСБИТ** *и. кимс.* Намуссыз һәм вөҗдансыз кеше. *Кеше арасында рисвай галәм ясагач, каршыңда көлеп торырга кушар идеңме әллә, оятсыз, тиресбит!* Т.Гыйззәт. *Син үткән ел җеназа вакытында миңа дигән хәерне чәлдердең, тиресбит...* С.Поварисов

**ТИРЕ́С ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Тирес гөмбәләре семьялыгының ак, соры, саргылт кыңгыраусыман эшләпәле, черемәле туфракта, тирестә, черек агач төпләрендә үсә торган бер ыругы; *русчасы:* **навозник**

**ТИРЕ́С КОҢГЫЗЫ** *и. зоол.* 1) Җәенкемыеклылар семьялыгыннан кыска канатлы, түгәрәк формадагы кара коңгыз, гадәттә тирес белән туена; *русчасы:* **жук-навозник**. *Тирес коңгызы кичен җиргә якын оча икән, көннәр матур торыр.* Сынамыш

2) *к.* **тирес корты** (*2 мәгъ.*). *Син аны белмисең, аны беркем дә белми, ул шундый тирес коңгызы, шундый коңгыз... Аны коры кул белән генә алып булмый, --- күзгә карап мыскыл итә, әшәкелек эшли.* Ә.Мушинский

**ТИРЕ́С КОРТЫ** *и.* 1) *зоол.* Май коңгызының личинкасы. *Шулай да без оя кырыена суалчан, тирес корты ише нәрсәләрне куеп карадык.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Кемне дә булса ачуланганда әйтелә торган сүз. *– Ах син, җирбит! – диде ул, секунд эчендә үзгәреп. – Әле син монда безнең ирләрне аздырып ятасыңмыни? Кәнтәй, тирес корты --- синең кебек кәнтәйгә нинди егет карасын?* Ф.Яруллин. *Ләкин нихәтле генә чеметсә дә, эчтән генә «тирес корты» дип көлсә дә, Гафур Гаяз Идрисовичның кыланмышларына түзәргә тиеш.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Бик сөйкемсез яки төскәбашка да ямьсез, күрексез кеше

**ТИРЕСКҮЗ** *и. к.* **тиресбит**. *Күп сөйләдек демократик сүзләр, Хуҗа булып йөри тирескүзләр.* Г.Афзал

**ТИРЕСЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тиресләү**. *Сафа, хатыны Саҗидә белән, ындыр артына чыгып, җиренең тиресләнгән өлешен китмән, көрәк белән казыды да казна биргән орлыкны чәчте.* М.Галәү. *Ул елны әлеге тиресләнгән җиргә чәчкән кукурузның гектарыннан ике йөз дә унҗиде центнер уңыш җыеп алдык.* В.Нуруллин

2) Тирескә әверелү. *Тиресләнгән салам өеме*

**ТИРЕСЛӘ́Ү** *ф.* Тирес белән ашлау, җир өстенә тирес таратып салу, тирес белән аралаштыру. *Җирне тиресләп яхшыртканнан соң, әүвәл арыш уҗымы вә богдай уҗымы чәчәләр.* К.Насыйри. *Торбалар сузып, суын үткәргәч, җирен әйбәтләп тиресләп, ашлап җибәргәч үсә ул әйбер, үсә.* Ф.Яруллин

**Тиресләп бетерү** Тиресләнәсе җирне тулысынча тиресләү; бөтен җирне тиресләү

**Тиресләп җибәрү** Бераз, берникадәр тиресләү

**Тиресләп кую** Алдан ук тиресләү, тиресләнгән хәлгә китерү. *Яшелчә бакчасын көздән тиресләп кую*

**Тиресләп тору** Һәрвакыт, гел тиресләү

**Тиресләп чыгу** *к.* **тиресләп бетерү**. *Чөгендер чәчәсе кишәрлекне тиресләп чыктык*

**Тиресли башлау** Тиресләргә керешү

**Тиресли тору** Даими яки әледән-әле тиресләү; озак вакыт дәвамында тиресләү эшен башкару. *Кырны тиресләп торсаң гына, уңыш уңа*

**ТИРЕСЛЕ** *с.* Тиресләнгән, тирес салынган; тирес белән аралаш. *Арыш йомшак вә мөлаем җирдә, тиресле җирдә яхшы уңа.* К.Насыйри. *Яз башыннан ук дым сеңдереп яткан тиресле бакча туфрагыннан үтәкүренмәле пар күтәрелә ---.* Т.Нурмөхәммәтов

**ТИРЕСЛЕК** *и.* 1) Тирес тупланган урын, тирес өеме. *Сары тавык, түл өчен азык эзләп, тиреслектә тибенеп йөри иде.* Н.Фәттах. *Рәниягә терлек абзары янындагы көрәнсу тирeслектә нәрсәдер селкенә кебек тоелды.* А.Вергазов

2) *күч. диал.* Тискәрелек, кирелек. *Шул рәвешле, саф хисләрнең татар арасында бу чорларда шактый ук нык тамырланган кирелек – тиреслекне җиңеп үтүе күрсәтелә, укучыда рухи канәгатьләнү тудыра.* А.Әхмәдуллин

◊ **Тиреслек башы** Авылның тирес түгә торган урыны, чүплек базы

**ТИРЕЧЕ** *и.* 1) Тире җыючы; тире эшкәртү белән шөгыльләнүче кеше. *Игенчеләр иген иккән, терлекчеләр мал-туар асраган, чүлмәкчеләр чүлмәк ясаган, тиречеләр тире иләп күн ясаганнар.* Н.Фәттах. *--- бу малайлар яз айларында, ярлырак башка авылдашлары кебек үк, дала-кырда йомран аулап, шуларның итен сабын кайнатучыларга, тиресен тиречеләргә сатып көн күрәләр.* Л.Хәмидуллин

2) Тире белән сәүдә итүче кеше. *Әти талчукта сату итә идеме, әллә тиречe идеме шунда – анысын яхшы белмим.* Г.Тукай. *Ул кыз --- тиречe Ибраһим байга хәләл җефет булган.* Ф.Әмирхан

**ТИРЕ-ЯРЫ** *җый. и.* Һәртөрле тиреләр; тире чималы. *Күршенең Питерпавлада булган вакытларында танышкан кешесе икән. Кәсебе дә бар: тире-яры, йон-ябага ише әйберләр белән сәүдә итүче.* М.Хәсәнов. *Мидхәтнең әтисе тире-яры җыеп көн итә иде.* Р.Мулланурова

**ТИРЛӘ́П-ПЕШЕП** *рәв.* Бик каты тырышып; зур көч куеп. *Шәйдулладан исә иҗади язу, сөйләү эше булмый. Тирләп-пешеп шактый утыргач, ул, укытучыдан котылу, чиратны уздыру өчен генә, ике җөмлә язып куйды: «Җәй көне мин әти белән урманга барганыем. Анда мин аю күрдем».* М.Мәһдиев // Арып-талып. *Ниһаять, Гөлсәйдә тирләп-пешеп кайтып керде: – Кеше шундый күп!* Ф.Яруллин

**ТИРЛӘТҮ** *ф.* 1) Тир барлыкка китерү, тир чыгарлык итеп эшләтү, куу һ.б. *Азымбай карт бу эш өчен, җәйләүдән җәйләүгә чабып, күп ат тирләтте.* Г.Ибраһимов. *Газинурның укуы турында сораштырды, бик кыен түгелме, диде. – Җиңел түгел, нык тирләтәләр, – дип җавап бирде.* Г.Әпсәләмов

2) *з.-сыз* Тирләргә туры килү, тирләүгә дучар булу. *Кояш бар көченә кыздыра. Җил булмаганлыктан бөркү, тирләтә.* В.Нуруллин. *Автобусның түбә капкачлары, тәрәзәләре ачык. Шулай да тынчу, тирләтә.* М.Хуҗин

**Тирләтә башлау** Тирләтергә тотыну. *Зәйтүнә якынайган саен, аның җылысы күкрәкләрне йомшартты, ниһаять, тирләтә башлады.* Ә.Низаметдинов

**Тирләтә төшү** Тагын да ныграк тирләтү; бераз тирләтү. *Тамак ялгаганнан соң ятып алсаң да ярар иде дә, моңа кадәр сизелмәгән тынчу һава Исмәгыйльнең борынына кереп, тәнен тирләтә төште.* Ф.Яхин

**Тирләтеп бетерү** Тәмам тирләтү. *Кура иясе атны яратмаса, атланып йөреп тирләтеп бетерә, кыйный, ашатмый икән.* Халык афоризмнары. *Шәфкать тә гүя Корычнурның уйларын укып ята. Ул, ну дәрт тә соң үзеңдә... тәмам тирләтеп бетердең, дигән булып, уң аягын юрган өстенә бөкләп куйды ---.* М.Шаһимәрдән

**Тирләтеп җибәрү** Тиз арада тирләтү. *Чәйдән соң тирләтеп җибәрде.* Ю.Әминев

**Тирләтеп чыгару** *к.* **тирләтеп җибәрү**. *Салкын тигәндә бал белән чәй эчү дә файдалы, хәзер тирләтеп чыгара.* Сәламәт булыйк!

**ТИРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәннең тир бизләреннән сыекча, тир бүленеп чыгу. *Аның белән сөйләшкәндә, Зарифуллинның борын очы тирләде, берөзлексез тотлыкты ---.* М.Мәһдиев. *Җәүһәргә ишелеп төшкән бу бәхеттән Илсөяр тиресенә сыеша алмас хәлгә килде. Битенә кан йөгерде, чәч төпләре тирләде.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Пар, бу чыгару, пар бөркеп тору. *Кап-кара сырма бәрхет булып сузылган кыр кояшка җылынып, тирләп, парланып ята.* И.Салахов

3) *күч.* Парлану, бу, пар куерып тамчы булып утыру; конденсат барлыкка килү. *Хәбибнең күзлек пыялалары тирләде.* М.Мәһдиев. *Зарифның кайнар сулышыннан тәрәзә пыяласы тирләп чыкты.* М.Хәбибуллин

**Тирләп бетү** *к.* **тирләп чыгу**. *Тирләп беттем, сулышым капты.* С.Сабиров. *Ул, чүгәләп, бер кулы белән улының тирләп беткән маңгайларыннан сыйпый, бармаклары белән юеш чәчләрен аралый.* Л.Ибраһимова

**Тирләп китү** Кинәт тирләү. *Фәтхерахман башта каушап, соңыннан ачуыннан кызарып, тирләп китеп, «әйе, әйе»дән башка җавап кайтармады.* К.Тинчурин. *Газинурның маңгае тирләп китте.* Г.Әпсәләмов

**Тирләп чыгу** Бик нык тирләү. *Бу хәлдән ул кинәт тирләп чыкты һәм үзенең төзәлмәслек бик зур ялгыш ясаганын сизә башлады...* А.Алиш. *Уф, башым авырта башлаган иде, хәзер арт чүмечем сызлый, култык асларым тирләп чыкты, манма су ---.* А.Гыйләҗев

**Тирли башлау** Тирләргә тотыну. *Галиулла Дорадан килгән хушбуй һәм яшь, көчле хатын исеннән тирли башлады.* З.Зәйнуллин. *Фарукҗан бер дә уйламаганда тирли башлады, шулай да сер бирәсе килмәде.* Т.Әйди

**ТИРЛЕ** *с.* 1) Тирләгән. *Төхфәтнең маңгае шактый эссе һәм тирле иде.* Ш.Камал. *Тузан-сөремгә буялып, каракучкыл төскә кергән тирле тәннәр бакырдан коеп куйгандай елкылдыйлар.* М.Хәсәнов

2) Тир белән чыланган. *Гофран абзый --- җәлт кенә киез эшләпәсен салды, аның эченнән беләүләнгән кәләпүш килеп чыкты, абзый күзләрен йомып, мыс-мыс килеп, шул тирле кәләпүшен иснәде ---.* М.Мәһдиев. *Рәшидә иртәдән бирле мунча стеналарын юып тирләгән һәм, тирле киемнәрен суга батырып, ялангач килеш эшләп ята иде.* Ф.Яруллин

**ТИРЛЕК** *и.* 1) Җиңсез эчке күлмәк. *Тирлекнең җиңе булмас, тиленең тиңе булмас.* Мәкаль. *Тирече тиресләгәндә тирлеген тирләткән.* Р.Һади

2) Ияр астына салына торган җәймә; чапрак. *Уктайның йөгәненә көмеш тәңкәләр тагылган, тирлек урынында зәңгәрсу келәм, келәм өстендә көмеш өзәңгеле ияр.* Р.Батулла

**ТИРМӘ** *и.* Төрки һәм монгол күчмә халыкларында, вакытлыча яшәү өчен, каркаска киез тарттырып эшләнгән, җиңел сүтелә һәм җиңел корыла торган түгәрәк торак; киез өй. *Уң якта, тигез дала уртасында, зур кибәннәр кебек тезелеп утырган тирмәләр иң элек аның күзенә чалынды.* Г.Ибраһимов. *Ул көнне ахирәтләр дала түрендә тирмә корып төн уздылар.* Р.Батулла

**ТИРМӘЛЕК** *с.* 1) Тирмә кору өчен билгеләнгән. *Тирмәлек киез*

2) Билгеле сандагы тирмә кадәрле. *1000 тирмәлек күчмәннәр группасы.* Р.Әхмәтьянов. *50 тирмәлек авыл*

**ТИРМӘН** *и. диал. к.* **тегермән**. *Бер хутлап җибәргәч бит, ул су тирмәне әйләнә дә тора ---.* А.Алиш

**ТИРҮ** *ф. диал.* 1) Нәрсәне дә булса берәмләп чүпләп җыю. *Карлыган тирү. Борчак тирү*

2) Тезеп чыгу, тезеп беркетү. *Стаканнарым тирән. Тирәсенә гөл тирәм.* М.Фәйзи

**ТИ́Р ХАСТАСЫ** *и. к.* **тиф**. *Аңа [Ильяска] ундүрт яшь тулганда, тир хастасыннан әтисе дә, әнисе дә үлеп киткәннәр.* Г.Әпсәләмов

**ТИРЧӘН** *с.* Тирләүчән, тиз тирли торган. *Кеше аты тирчән, кеше киеме керчән.* Мәкаль

**ТИ́Р ЧИРЕ** *и. к.* **тиф**

**ТИРЬЯК** *и. гр. иск.* 1) Агу кайтаргыч. *Кулыңдагы тирьякка ышанып, агу эчмә.* Мәкаль. *Галимнәр – тирьяктыр, җаһилләр – агудыр.* К.Насыйри. *Табиб тирьяк тәкъдим итте. – Синең бар белгәнең тирьяк инде, – дип, аны да ошатмады тәтә. Табибның иң курыкканы агу иде.* М.Әмирханов

2) *күч.* Шифа, дару. *И матур кыз! Зәһрә [агуга] тирьяктыр кулың.* Г.Тукай

**ТИС** *и. слав. бот.* Тисчалар семьялыгыннан җылы якларда үсә торган кызгылт кайрылы, ачык кызыл җимешле, кыйммәтле каты үзагачлы мәңгеяшел ылыслы агач. *Советлар иле таркалгач, Россиядә тис кыргый хәлдә үсә торган хәзер бер генә урын калды.* Ф.Вәлиев

**ТИСКӘРЕ** *с.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса уң, йөз ягына каршы булган; эчке, сул, тыштан караганда күренми торган. *Йөзе йокыдан таушалган, күзләре рәтләп ачылып та җитмәгән, башындагы яулыгын да тискәре ягы белән япкан.* Г.Әпсәләмов. *– Габделбай абзый бик мәзәк иде, иеме, әткәй? – диде бусага төбенә чүмәшкән килен. – Күлмәген тискәре яктан кияр иде. Байыйм, дип.* Н.Гыйматдинова

2) Берәр нәрсәнең уңаена, төп юнәлешенә капма-каршы; кире. *Әллә инде ул [эт] салмыш хуҗасының тупас уйнавына, йонын тискәре якка сыйпавына, танавына сугуына үпкәли, әллә инде аягын тешләгәнгә үзен гаепле санап йөри?!* Я.Шәфыйков

3) Берәр нәрсәнең уңай якка булмавын раслый торган; көткәнгә капма-каршы булган, капма-каршы эчтәлекле, кире. *Сталинга, кабул итүен үтенеп, өч-дүрт мәртәбә хат белән мөрәҗәгать итте. Әмма алар, суга төшкән сыман, эзсез югала барды: ни уңай, ни тискәре җавап алынмады.* Р.Мөхәммәдиев. *Совет чорында иллюзиядән килеп туган «йөз процентлы өлгереш» кампаниясе торгынлык чорында формализмга, күз буяуга әверелгән булса, соңгы реформа һәм контрреформа, дөресрәге, башбаштаклык, хәтта башсызлык елларында бөтен тискәре нәтиҗәләрен бирде.* Р.Вәлиев

4) Тиешле яки төп тарафка каршы булган, каршы юнәлештәге. *Күршесенең, капкадан чыгып, тискәре якка китүен Әсмабикә күреп калды.* Г.Исхакова. *Ләкин агач һәрвакыт син теләгән якка аумый, я тискәре җил исә башлый, я кәүсәсе үзе авыш була.* З.Мурзиев

5) Кире, кеше сүзен тыңламаучан, тыңлаусыз, кеше сүзенә каршы килүчән; үҗәт. *Мин, әтисенең сүзен тыңламаган тискәре малай кебек, үземне әкрен йөрергә гадәтләндерә алмыйм.* С.Кудаш. *Әмма, нинди тискәре кеше булса да, өлкәннәр сүзен егарга кыймады, ахры: – Ярар, – диде, кулын селтәп.* Д.Булатова

6) Начар, әшәке, яман; ямьсез; негатив. *Ләкин, барыннан да элек, аның үз-үзен артык иркен тотышы егеттә тискәре тәэсир калдыра.* Г.Рәхим. *Хәзерге көндә безнең бик күп җырларыбыз халыкка тискәре йогынты ясый.* Р.Вәлиев // Җайсыз, аяусыз. *Әрли-әрли ләгънәт әйтәм тискәре бу дөньяга.* Г.Тукай

7) Көтелгәнгә, таләп (яки өмет) ителгәнгә каршы; уңай булмаган, нәрсәне дә булса хупламый торган, әһәмиятен танымый, инкяр итә торган. *Бу сүзләремне укып, бу мөхтәрәм шәхес турында моңарчы гел тискәре сүзләр генә ишетеп, миләре тәмам агуланып өлгергән укучыларым сагаеп кала күрмәсеннәр.* А.Хәсәнов. --- *«цивилизаторлар», «милләтпәрвәрләр» тырышлыгы белән татар мәгарифе яңадан унитар урыс мәгариф системасына куып кертелде. Бүгенге рухи-илаһи тәрбияне эченә алган концепциягә дә тискәре бәяләмәләрне нәкъ шулар бирә.* Ә.Илдус // Өнәмәү, яратмау яки дошманлык хисләре белән сугарылган. *Сул фикерле матбугат мәйданыннан либераль-буржуаз газетага күчүе ул заманның алдынгы карашлы эшлекләрендә гаҗәпләнү һәм тискәре тойгылар да тудырган ---.* Г.Камал. *Гомергомергә күрше булып яшәсәләр дә, бик күпләре «Исәнмесез!» --- дигән гап-гади сүзләрне дә белми ләбаса! Мин элегрәк, бу аларның татарларга тискәре карашы аркасында гынадыр, дип уйлый идем.* Э.Халидов

8) Әдәбият һәм сәнгатьтә: уңай булмаган, кире, негатив. *Патша хөкүмәтенең татар демократик культура учакларына, әдәбиятына каршы юнәлдерелгән реакцион политикасы XX гасыр башы татар әдәбиятында зур чагылыш таба: әдәбиятка өр-яңа тискәре образ килеп керә.* М.Мәһдиев. *Габдулла Тукай иҗатында уңай идеаллар, фәлсәфи-эстетик карашлар тискәре типларны рәхимсез фашлау аша чагылыш тапкан.* Т.Галиуллин

9) Реакцион, карагруһчыл, алдынгылыкка, яңалыкның үсешенә каршы торган. *Ул [Г.Камал] демократик карашлар позициясендә тора һәм --- тискәре көчләргә каршы сугыш ача.* М.Гали

10) *мат., физ.* Нульдән түбән, минус тамгасы белән билгеләнгән, минус билгесе белән йөртелә торган. *Уңай һәм тискәре саннар белән гамәл кагыйдәләре озак еллар буе кушу һәм алу очраклары өчен генә тикшерелгәннәр.* Алгебра. *Тискәре температураларда куллану өчен, коры катнашмалар составына туңуга каршы өстәлмәләр – поташ, --- формиат кертелә.* Төзү материаллары

11) *физ.* Артык электроны булган. *Индий атомы, германий атомнары белән бәйләнешкә кергәндә, дүрт валентлы элементка әверелергә омтыла һәм германий атомының бер электронын үзенә алып, тискәре ионга әверелә.* Р.Шаһморатова. *Табигатьтә җылы һәм салкын, унай һәм тискәре корылмалар булган кебек, кеше дә капма-каршылыклардан тора.* З.Фәтхетдинов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Икенче, кире, каршы як. *Өстәлгә кайтарып салынган тузанлы панбәрхет тукымасының тискәрегә каршы өслегендәге эре асылташ, зур зөбәрҗәт ташлар кидертелгән ике балдак, тагын ни нәрсәләрдер җемелдәшеп тора иде.* Ә.Гаффар. *Уйнап әйткән сүземне дә Тискәрегә борасың.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

2) Төньяк. *Көзге сагыш. Тискәредән салкын җилләр исә, Басып алган көзне сарысы.* И.Киньябулатов

3) Начар, уңай булмаган, күңелсез хәл, вакыйга һ.б.ш. *Әдәбият тормыш һәм кешеләр турында белем бирә, яхшыны яманнан, изгелекне явызлыктан, уңайны тискәредән, гүзәллекне ямьсезлектән аера белергә өйрәтә.* Ф.Ганиева. *Бала Талипны үзгәртер әле, һичшиксез үзгәртер, диде. Ә ир анда хәтле ун тапкыр «үзгәрде». Гел тискәрегә.* Н.Гыйматдинова

4) Кире, сүз тыңламаучан, үҗәт кеше. *Шуннан соң Мәнзүрә, бу тискәрене үртәп: «Ялындыра, ялындыра, ялындыра – килми ул, килер иде, уйнар иде – бию көен белми ул», – дип, минминлегенә тиярлек итеп басым ясамакчы булды.* Р.Кәрами. *Нәрсә булсын! Нәрсә көтеп була Менә моныңише тискәредән!* М.Кәбиров

◊ **Тискәре бару** Нәрсәгә дә булса һәрвакыт яки турыдан-туры каршы булу, ризалашмау. *Җаббар абзый, син бүген сул ягың белән торгансың, ахры: һәрбер сүзгә тискәре барасың.* Г.Ибраһимов. **Тискәрегә сукалау** Нәрсәне дә булса үзе теләгәнчә таләп итү, үҗәтләнү, киреләнү. *– Кешеләр җитми, шуның түбәсен ябышырга ярдәм ит. – Ник соң әрмәннәр үзләре ябып та бирми? Түбәсенә калгач кына... – дидем, тискәрегә сукалап.* Н.Әхмәдиев. **Тискәре килү** *к.* **тискәре бару**. **Тискәре тибү** Кискен, тупас рәвештә кире кагу. *Әмеребезне тискәре типкән өчен --- Җиргә аттык без моны [Иблисне] мәхрүм итеп.* Ш.Бабич

**ТИСКӘРЕ́БЕТКӘН** *с. сөйл.* Үҗәт, үзсүзле, киребеткән. *Иң элек Йосыфлар йортына Патый барып, ахирәте Сылу һәм тискәребеткән карт белән сөйләште.* М.Галәү

**ТИСКӘРЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Карышу, әйтелгәнне үтәмәү, кушылганны тыңламау, киреләнү, үзсүзләнү, үҗәтләнү. *Әмма Вәлит тискәреләнде, дәресләргә дә ара-тирә, анда да шул «килде» исеме өчен генә барып йөрде.* В.Имамов. *Рәшит бар егәрен туплады, үҗәтләнеп, тискәреләнеп: – Менәм, барыбер менәм! – дип пышылдады.* Д.Булатова

2) *күч.* Кирегә, артка китү, начар якка үзгәрү; юкка чыгу. *Аның [Зыяның] барлык таланты тискәреләнер дә, барлык өмите кирегә китеп, --- үзенә әллә ниләр булыр.* Г.Ибраһимов

**Тискәреләнә бару** Торган саен ныграк тискәреләнү. *Баланың холкы тискәреләнгәннән-тискәреләнә бара*

**Тискәреләнә башлау** Тискәреләнергә тотыну. *Кола бия Олы Чокырга җитәрәк бөтенләй тискәреләнә башлады.* К.Булатова. *Атлылардан калмаска тырышып, назлы сүзләр дә, тискәреләнә башлаганда тупасракларын да ычкындырып, үгезен әйдәләп, Хәдичә йөк өстендә бара.* Кызыл таң

**Тискәреләнеп алу** Берара тискәреләнү. *Өстен япкач, кызы бераз типкәләнеп, тискәреләнеп алды да тагын изрәп йоклап китте.* Ч.Мусин

**Тискәреләнеп китү** Кинәттән тискәреләнү

**Тискәреләнеп кую** *к.* **тискәреләнеп алу**. *Апа балалар кебек кинәт бер тискәреләнеп куйды*

**ТИСКӘРЕЛЕК** *и.* 1) Үзсүзлелек, кирелек, холыксызлык. *Тискәре адәм болай да тискәрелеге аркасында бәхетсез инде.* Т.Әйди. *Үгезнең тискәрелеге шул ук үрдә икенче көнне дә кабатланды.* Н.Әхмәдиев

2) Реакционлык, карагруһчылык. *Үзсүзле кешеләр, тискәрелек һәм фанатизм әһелләре хак сүз сөйләмиләр һәм хаклыкны кабул итмиләр.* Р.Фәхретдин. *Искелек, тискәрелекнең дә аръягына барып чыккан бу мулла үзе артык дәрәҗәдә беркатлы кеше иде.* З.Бәшири

**ТИСКИ** *и. рус тех.* Эшкәртелә торган детальне беркетеп куя торган җайланма; кыстыргыч, эскәнҗә. *Беркөнне мастер, миннән бер генә тиски аркылы эшләгән карт слесарь Аникин янына килеп, аны каядыр бер эшкә җибәрде.* Ш.Усманов. *Детальләрем тискига кысыла төшкәндә, тешләрем дә ныграк кысылды.* Н.Хәсәнов

**ТИ́СЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Йомшак, уртача яки субтропик климатлы өлкәләрдә таралган, башлыча мәңгеяшел куак һәм агачларны берләштергән ылыслы үсемлекләр семьялыгы

**ТИТАКЛА́У** *ф.* 1) Титак-титак итеп атлау, чатанлау. *Вагон баскычыннан зур авырлык белән төште дә, вокзал бинасын үтеп, сулга, кеше күп кайнашкан билет сату кассалары, саклык камералары ягына титаклады...* З.Зәйнуллин. *Стройга тезелеп киләләр. Иң алда Сабир карт титаклап бара.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Берәр эш яки хәлнең торышы канәгатьләндерерлек булмау; аксау. *Эш барса, нигездә хуҗаларны мактадылар, колхоз әз генә «титаклый» башласа, сәяси вожаклар сәбәпче булды.* Т.Нәҗмиев

**Титаклый башлау** Титакларга тотыну. *Майор адымнарын ешайтты, шул ук вакытта карт та ашыгыбрак титаклый башлаган кебек тоелды аңа.* З.Фәтхетдинов

**Титаклый бирү** Титаклауны дәвам итү. *Тәмеч абзый, сезнең кайгы юк әле монда дигәндәй, вак-вак адымнар белән титаклый биреп, Вачутасы янына ашыккан була...* З.Зәйнуллин

**ТИТА́К-ТИТАК** *рәв.* Сыңар аякка чатанлап, як-якка ихтыярсыз тайпылгалап. *Сыңар култык таягы белән титак-титак аксаклап йөри иде әле Мөнир ул вакытта.* Р.Төхфәтуллин. *Хатын титак-титак шунда атлады.* Н.Гыйматдинова

**ТИТАН** I *и. гр.* **1.** 1) *миф.* Борынгы грек мифологиясендә Уран һәм Геяның (Күк һәм Җирнең) Зевс тарафыннан җиңелеп, Тартарга бәреп төшерелгән улларының берсе. *Алтайлыларның мифлары грек мифларын һәм анда тасвирланган титаннар сугышын хәтерләтә.* Н.Фәттах. *Кәримәне университетның ак мәгъърур колонналары каршы алдылар. Һаман да фәннең бөеклеген саклап басып торучы титаннар кебек иде алар.* Ф.Яхин

2) *күч.* Берәр өлкәдә гаять зур эшчәнлек күрсәткән шәхес. *Хәтта Блок, Пастернак, Есенин кебек титаннар, балалар өчен язарга тырышып та, уңышсызлыкка очраганнар.* Р.Миңнуллин. *А.Фадеев Ибраһимов әсәрләрен югары бәяләде, Л.Соболев аны, татар әдәбиятының титаны, дип атады.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ. к.* **титаник**. *Кара диңгез. Монда титан куәт! Тауга охшап, дулкын ишелә.* Ш.Мөдәррис. *Таш гасырдан калган сөңге булып, Болытларга баткан очлары. Таулар – гүя ташка әверелеп Катып калган титан дулкыннар.* Р.Миңнуллин

**ТИТАН** II *и. гр. хим.* **1.** Корыч төсендәге, коррозиягә һәм кызуга чыдам каты металл, химик элемент. *Галимнең бронза сыны титаннан ясалган дуга сыман биек корылма астына – гранит ташка урнаштырылган.* Т.Әйди. *Профессор өстендә калай күлмәк һәм калай ыштан, аякларына титаннан ясалган ике тәлинкә тимерчыбыклар ярдәмендә уратып куелган.* Р.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул металлдан эшләнгән. *Мин чүкечемне кысыбрак тоттым, һәм без эшләп киттек. Клёпкалар, титан калайларын беркетеп, иңеп бара.* Н.Хәсәнов. *Сынарлар хәтта урталай титан кораблар.* Ф.Яхин

**ТИТАН** III *гр.*: Эчендә махсус җылыткыч урнаштырылган калай цилиндр, бак рәвешендәге су кайнату җайланмасы. *Шул ук минутта ул, утка баскан песидәй кабаланып, титаннан кайнар чәй дә агызып алды.* Н.Фәттах. *Аның кушуы белән Салиха апа коридордагы титаннан бер чәйнек кайнар су алып кергән арада, яңа танышның сумкасыннан өйдә пешкән пәрәмәчләр, ярты литрлы банка белән авыл каймагы чыгып өстәлгә урнашкан иде инде.* Н.Гыйматдинова

**ТИТАНИЗМ** *гр.* Титаннар кебек зур эш башкарырга дәгъва һәм омтылыш. *Дөрес, «Җир уллары»ннан соң да аның [Такташның] шигырьләрендә «даһилык», «титанизм» шаукымы, мифик образлар яши әле.* Х.Госман

**ТИТА́НИК** *с.* 1) Титаннарга хас булган, титаннарга охшаган; титаннар кебек бик көчле, бик куәтле. *Исхакый иҗатын, аның иҗтимагый яисә*

*фәлсәфи фикерен читләтеп үтү мөмкин түгел. Бу титаник шәхес XX йөз әдәбияты, иҗтимагый фикере үсешенә юнәлеш биреп торучы милләтпәрвәр, халык бәхете өчен яшәүче изге зат буларак елдан-ел тирәнрәк ачыла*. Т.Галиуллин. *Матбугатта милли темага сүз әйтү дә мөмкин булмаган ул елларда Илһам Шакиров татар җанын, татар күңелен тере итеп саклап калу өчен иң зур эш башкаручы булды бит. Титаник эш башкаручы!* М.Вәлиев

2) Гаять көчле, куәтле һәм бик киеренке. *Ватаныбызның язмышы өчен хәзер бара торган титаник көрәшләрдә батыр сугышчыларның һәркайсы --- бөек идея хакына кабахәт фашистларны кыралар*. Г.Иделле

**ТИТАНЛЫК** *и.* Титан булу. *Генийлык, даһилык титанлыкның бер бүлемтеге генә. Бездә, татарда, әлегә бер генә титан бар: Исхакый*. А.Хәлим

**ТИТАННА́РЧА** *рәв.* Гаять зур көчкуәт белән, егәр-гайрәт белән. *Титаннарча көч түгелгән юлдан, шундый зур казанышларга китергән юлдан, аның, кайчандыр бунтарь, главарь булган кешенең --- табигыйлеккә кайтуы җиңел түгел иде*. Х.Туфан. *Ул яшь килеш, үз халкын яңа, якты тормышка чыгарыр өчен, каләм белән көрәш башлады, кыска гына гомерендә титаннарча эшләп, гасырларга, күп буыннарга мәгънәле, файдалы иҗат калдырды*. М.Мәһдиев

**ТИТАРАЙ** *с. диал.* **1.** Бик шук, артык шаян; тотнаксыз. *[Кызбикә:] Кара инде титарай кызны, тәсбихлы бүкән була, диме*. М.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Дуся күзгә күренеп инде юаная иде, һәм күршекүләнгә ара-тирә Минҗан карт әйткәләп куя иде: – Безнең титарай сугышта да тик ятмаган; терекөмешне тегендә үк йөгерткән булган*. М.Мәһдиев

**ТИТАРАЙЛЫК** *и. диал.* Артык шуклык, шаянлык; тотнаксызлык. *Була шундый матур кызлар авылларда, була. Әмма егетләр игътибарыннан башы әйләнеп, титарайлыкка чыкканнары, кияүгә барганчы ук әллә ниткән хаталар эшләп бетереп дан чыгарганнары да була*. М.Мәһдиев

**ТИТАРАК** *с. к.* **титарай**

**ТИТЕ́СТЕР** *и. ингл.* Чәй сортын билгеләүче белгеч; чәй дегустаторы. *Чәй фабрикасының баш титестеры*

**ТИТИ** *и. сөйл.* 1) Тавык. *– Әтәчләре бер кетәк, титиләре генә аз икән шул, – диде аңа каршы икенчесе*. Ф.Сафин. *Әнә, Гайшә түтәйнең алып кайтканына да ике атна бар инде, тик менә титиләрме, әтәчләрме икәнен белгән юк*. Ф.Баттал

2) *куч. к.* **титибаш**. *Тыңла, тити!*

**ТИТИБАШ** *и. сөйл.* Томана, ачыгавыз, аңгыра. *– Энем, титибаш! Шушы әртискәгә малларны ышандырдыңмы? – дип, карчык, пырылдап, абзарда әле бер, әле икенче сыерның имчәген тартты*. Н.Гыйматдинова

**ТИТИБИКӘ** *и. сөйл.* 1) Тавык. *Уйларымны әтәч кычкырганы бүлде. Хуҗаларның әтәче. Аның эше рәхәт – титибикәләре янында, мәхәббәт газабы кичереп интегәсе юк*. Н.Әхмәдиев. *Ә йомырканы үзебезнең титибикәләр дә җитәрлек салып тора, шөкер*. Ш.Маннанов

2) *кимс.* Томана, ахмак хатын-кызга карата хурлап, кимсетеп әйтелә; аңгыра, тавыкбаш. *Аның турына килеп җиткәч, арада калкурак гәүдәле берсе: – Әй, титибикә, күкәеңә салкын тигерә күрмә! – дип кычкырды, һәм алар шаркылдашып көлешергә тотындылар*. Ф.Садриев

**ТИТИ-МИТИ** *и. сөйл.* Акча. *Басыйр акчага ишарәләп, бармакларын уйнатты: тити-мити кирәк*. Н.Хәсәнов. *Соң үзең уйлап кара: компанияне теркисе, лицензия аласы, эшчеләргә зарплата түлисе, налогы-мазары дисеңме – барысына да акча, кем әйтмешли, тити-мити кирәк бит*. Ф.Имамов

◊ **Тити-мити уйнау** 1) Җитди булмаган эш белән шөгыльләнү; 2) Җитди эшкә игътибарсыз карау. *Ә дошман белән без тити-мити уйнап маташмыйбыз. Без дошманны юк итәбез*. Х.Вахит; 3) Кем белән дә булса мавыгу, гыйшык уены уйнау. *Ир-ат халкы бит ул әзрәк читтә тити-мити уйнарга ярата*. Р.Рахман. *Оятсыз! Тити-мити уйнар алдыннан микрофоныңны сүндерер идең хет!..* Д.Гыйсметдин

**ТИ-ТИ-ТИ** *ы.* Тавыкларны чакырганда әйтелә торган сүз. *Ти-ти-ти, дип тавыкларны чакырырга тотынган идем, казлар гаңгылдаша башлады, абзардагы дуңгыз мыркылдарга кереште, эт тә, өреп, аларга кушылды*. Т.Миңнуллин. *– Ти-ти-ти, ти-ти-ти... – Күтеп кенә торганнар, күрәсең: бар тавык-кош җим салынган табак тирәсенә җыелышты*. Ф.Мөслимова

**ТИТР** *и. лат.* 1) Фильм кадрындагы язу: күрсәтелгән кешеләрнең сүзләре яки башка аңлатмалар. *Экран аша укылырга тиешле бер текстка шундый матур титр язып куйды*. А.Хәсәнов. *Экранда фильмның титрлары күренүгә, хатын, үрелеп, Шәүкәтнең колагына нидер пышылдады*. М.Маликова

2) *хим.* Титрлау өчен эретмә

**ТИ́ТРЛАУ** *ф. хим.* Концентрациясе билгеле булган эремәне анализлана торган икенче бер эремәгә төсен үзгәрткәнче (яки утырым хасил булганчы) тамчылап өстәү. *Алынган пробаларны, индикатор салып, селте белән титрладылар*. А.Расих. *Эремәнең гомуми әчелеге 60, ә иректе әчелеге – 12 «нокта» (фосфатлау эремәсен нейтральләштерүгә – титрлауга киткән NaOH эремәсенең күләме)*. Фән һәм тел

**ТИ́ТУЛ** *и. лат.* **1.** 1) Кешенең нәселе-затына яки урыны-чинына һ.б.га карап бирелгән югары дәрәҗә атамасы. *Солтан титулын хан хатыннары да йөрткәннәр, мәсәлән, Фатыйма солтан...* Б.Хәмидуллин. *Хованский --- бояр, кенәз титулларына ия. Нәселләре атаклы һәм затлы анысы*. В.Имамов

2) Кешенең бер өлкәдә квалификациясен яки эш-хезмәттә тоткан урынын рәсми билгели торган атама; дәрәҗә, гонван. *Аның «хафиз» дигән титулыннан Коръәнне яттан белүче булган икәне аңлашыла*. А.Гайнетдинов. *1998 елда Р.Габдрахманов Татарстан һәм Россия беренчелегенә уздырылган ярышларда чемпион титулын яулый ---*. Г.Мөхәммәтшин

3) *полигр.* Китапның исеме. *Титулын эре хәрефләр белән бирү* // Китапның яки китап рәвешендә эшләнгән башка басмаларның (атлас, альбом һ.б.ның)

исеме, авторы, басылып чыккан елы һ.б. язылган беренче бите. *Титул битенең башында русча автор исеме, астарак – немецча ---.* М.Җәлил. *Китапны --- өстәл тартмасына салдым да тартмада килеш кенә титул битендәге сүзләрне укыдым: «Адаш! ---».* М.Шабаев

4) *юр.* Берәр хокук субъектының рәсми исеме. *Бу төбәк халкы 2500 еллар дәвамында --- күп этнослы олы сәяси-административ берәмлекләр составына кереп яшәгән: кимирлар, скифлар, һуннар, Төрек каганаты, Хәзәр каганаты, Алтын Урда, Мәскәү патшалыгы, рус империясе ---. Бервакытта да руслар бу берләшмәләрнең чикләнмәгән титул халкыннан булмаган дияргә була.* М.Гайнетдин

5) *юр.* Берәр хокукның нигезе, аның эчтәлеген чагылдырган исем

**2.** *с. мәгъ.* Дәүләтнең яки федерация субъектының рәсми исемен билгели торган, анда яшәүчеләрнең төп өлешен тәшкил иткән. *Автономиягә генә ия республиканың титул милләтенә совет заманында энциклопедия тәтемәде: рөхсәт булмады.* Б.Рәхимова. *Инде аңа Уфа губернасын китереп кушкач, титул халык булып татарлар да саналырга тиеш бит.* Татарстан яшьләре

**ТИ́ТУЛЛЫ** *с.* Титулы (*2 мәгъ.*) булган; дәрәҗәле, атаклы. *– Титуллы Җиһанов --- булуга караганда титулсыз, чинсыз Сәйдәш --- булуга ни җитә? – дип уйлыйм мин үз турымда.* Х.Туфан. *Дәрәҗәле турнирны меценат һәм титуллы көрәшче Ленар Гаянов --- Түбән Кама Башкарма комитеты белән бергә оештырган.* Мәйдан

**ТИФ** *и. гр. мед.* Бизгәк тоту, аң чуалу белән бара торган кайбер йогышлы авыруларның уртак атамасы. *Тоткыннар арасында тимгелле тиф, дизентерия кебек йогышлы авырулар башланды.* Г.Әпсәләмов. *Ул кышны барак халкы өч төрле авырудан: тифтан, бизгәктән, үпкә чиреннән кырылды.* Ф.Бәйрәмова

**ТИФЛОГРА́ФИКА** *и. гр.* Техниканың сукырларны рельефлы рәсем ясарга, рельефлы сызым сызарга һәм башка уку предметларын үзләштерергә өйрәтү өчен кулланмалар проектлау һәм әзерләү белән бәйле тармагы

**ТИФЛОПЕДАГОГ** *гр.* Сукырлар яки начар күрүчеләр белән эшләүче педагог, укытучы. *Соңрак энциклопедиядән укып белдем: Луи Брайль 1809–1852 елларда яшәгән француз тифлопедагогы икән.* Фән һәм тел. *Тифлопедагог дипломы*

**ТИШЕК** *и.* **1.** 1) Тишелгән, ертылган яки буш, ачык калган урын. *Кар урынына биткә салкын ком бәрә, баракның һәр тишегеннән эчкә бозлы ком тула.* Ә.Баян. *Безгә шул ертык шинель тишегеннән төшкән яктылык җиткән.* Ф.Яруллин

2) Нәрсәнең дә булса эчендәге бушлык, кечкенә куышлык. *Нургалинең исә чәч араларына, колак тишекләренә ком тулган, өстеннән су, чалбар кесәләреннән ташлы ләм ага, күзләре пыялаланган.* М.Мәһдиев

3) Гадәттә, махсус ясалган тирән яисә үтәли уентык, ачыклык. *Шайтан вәсвәсәсе булгандыр инде: шулай итеп, мин аны Ясәвигә илтеп бирмәдем, әткәйләр келәтенең песи йөри торган тишегеннән эчкә ыргыттым.* Т.Гыйззәт. *Кызчык төн уртасындарак Гыйлемдарның, үләннәрне ера-ера, койма тишегенә таба киткәнен күреп калган була.* Г.Әдһәм

**2.** *с. мәгъ.* Тишелгән. *Берәүләр бар яктан җитеш тормышта яши, икенчеләр, әнә теге ятим малай кебек, тишек ботинка белән йөри.* Х.Камалов. *Күпмедер вакыттан соң тишек түбәдән шыпшып тамчы тамганын тоеп, ул тагын күзләрен ачып җибәрде.* Н.Фәттах

◊ **Тишек авыз** Бар белгәнен һәркемгә сөйләп йөри торган, сертотмас кеше. *Әмма сүзендә тормаган, ди, теге тишек авыз, хатынына әйтмичә түзә алмаган.* Г.Бәширов. *И, ул тишек авызны, бирермен әле мин аңа, әллә нинди ят абыйларга минем исемне әйтеп йөрмәсә тагын...* Р.Кәрами. **Тишек бер тиен** Кыйммәте, файдасы юк дәрәҗәдә аз булган, бернигә дә тормаган, кирәкмәгән нәрсә турында. *Тоткынның гомерен тишек бер тиенгә дә санамый ич алар ---.* М.Әмирханов. *И-и, юләр хатын, юләр хатын, тишек бер тиенгә торырлык та акылың юк икән.* Ш.Җиһангирова. **Тишек бер тиен кебек әйләнеп кайту** Кирәксез, әһәмиятсез кешенең яки нәрсәнең көтмәгәндә кайтып төшүе турында. *Ретро, искелек тишек бер тиен кебек ул, җаныкаем, әйләнә дә кайта.* Татарстан яшьләре. **Тишек борын** Юньсезрәк малайларга карата үз итеп әйтә торган сүз. *– Улым, бар, киленгә әйт әле, алып чыксын кучтәнәч кәнфитләрен, шунсыз китмәсләр бу тишек борыннар, – дип, Зариф абзый чак тынычландырды үзләрен.* Г.Галиева. *– Юуга килгәндә, күр минем каенишләрне, ярдәм итәргә атлыгып торалар, тишек борыннар, – дип ялгады ул, үзләрен урап алган малай халкына ишарәләп.* А.Тимергалин. **Тишек көймәгә утырту** *к.* **тишек чуманга утырту**. *Борын төбеннән бәхетен урладылар. Дәүләтхан нәселен тишек көймәгә утырттылар, үзеннән көлделәр!* Р.Камал. **Тишек чуманга утырту** Кемнедер алдау. **Тишеккә тыгын (ямау) булып йөрү** 1) Билгеле бер вазифасы булмыйча, кая кушсалар, шунда йөрү; 2) Кирәкмәгән эшкә катнашып йөрү. **Тишеккә ямау салу** Мәсьәләне төптән хәл итмичә, вакытлыча яки күз буар өчен чыгу юлын табу. *Милли китапханәне башка бинага күчерү тишеккә ямау салу гына.* Безнең гәҗит. **Тишек танау** *к.* **тишек борын**

**ТИШЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **тишекләү**. *Яңа чүпрәдән куйган чемердәп торган йөгерек камырның әчкелтем тәмле исе борын эчләренә үтеп иркәләде, чаж итеп кызу табага коелуы, ничек итеп пыш-пыш килеп тишекләнеп кыбырдап-кыбырдап алуы[н], --- ишетеп --- ятты карт.* Х.Мөдәррисова

2) *төш. юн. к.* **тишекләү**. *Төбе берничә җирдән тишекләнгән чиләк бакчада аунап ята*

3) *күч.* Хәтер тузу. *Картаелды инде, хәтер дә тишекләнде*

**Тишекләнә башлау** Тишекләнергә тотыну

**Тишекләнеп бетү** Тәмам, бик нык тишекләнү. *Карчыклар Сәүрә карчыкны мөнәҗәт әйтергә кыстый башладылар. – Кая ул, ю-ук, хәтерем начарланды. Диһенем тишекләнеп бетте инде. Бернәрсә хәтеремдә калмай.* М.Юныс. *Әллә, киресенчә, шулай кул-*

*дан кулга күчә-күчә, тикшерелә-тикшерелә тишекләнеп беткәнме ул [эскәтер]?* А.Хәлим

**ТИШЕКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Махсус рәвештә тишү; тишекләр ясау. *Килгәндә, һәрберсе, салганда ук өстен бармак белән тишекләп, остабикәгә дип билгеләнгән берәр бөтен икмәк күтәреп килер иде.* Гали Рәхим. *Тәрәзәләргә тишекләп чигелгән пәрдәләр эленгән.* Туганайлар

2) Күп җирдән тишү; тишкәләү. *Койманы тишекләү*

**Тишекләп бетерү** Нык тишекләү

**Тишекләп карау** Сынау өчен тишекләү

**Тишекләп кую** Алдан ук тишекләү, тишекләнгән хәлгә китерү. *Комлыкның нигезенә калын полиэтилен плёнка, геотекстиль, тротуар плиткасы, хәтта алдан тишекләп куелган фанера салырга мөмкин ---.* Туган як

**Тишекләп тору** Даими рәвештә тишекләү; хәзерге моментта тишекләү

**Тишекләп чыгу** Булган берсен рәттән тишекләнгән хәлгә китерү

**Тишекли башлау** Тишекләргә керешү

**ТИШЕКЛЕ** *с.* 1) Тишелгән яки табигый хәлендә дә үзендә тишек була торган. *Музей курайларының берсе, әллә ясалып бетмәгән иде, бер генә тишекле булып чыкты.* Р.Батулла. *Диңгез буенда ял итүчеләр яр читендә тишекле түгәрәк таш тапсалар, үзләрен бәхетле санныйлар, үзләренә бәхет юрыйлар.* Г.Рәхим

2) Тишекләре күп булган, тишкәләнгән. *Әнә урам коймасы өстеннән Газдалның вак-вак тишекле ак капрон эшләпәсе күренде.* Ф.Садриев. *Бу балыкны бер-ике мәртәбә вак тишекле иттарткычтан үткәрегез дә котлет әвәләп ашагыз.* З.Мурсиев

◊ **Тишекле бер тиен** *к.* **тишек бер тиен**. *Ильясның монда керәге – тишекле бер тиен. Монда аны кызганып, үксез баланы рәнҗетмәс өчен, ярдәм итәр өчен, шәфкать йөзеннән, Ходай каршында савап өчен генә сыендырдылар.* Ә.Баян. **Тишекле бер тиен кебек әйләнеп кайту** *к.* **тишек бер тиен кебек әйләнеп кайту**. *Мескен Захарычның сүзләре алтын булганнар икән. Авыл белән тамга җыйган булдык. Приговор бирдек. Берсе дә эшкә ашмады, тишекле бер тиен кебек кайтып та килгән.* Т.Гыйззәт

**ТИШЕКЛЕ́-ТИШЕКЛЕ** *с.* Беришле тишекләре булган, күп тишекле. *Имән бармагына тишекле-тишекле уймак кигән сөякчел кулы елт-елт итеп тукыма кисәге өстендә йөри.* М.Галәү. *Ул аның алып килгән бик тәмле төсле, сап-сары, тишекле-тишекле коймакларына кагылмады, кулын да сузмады.* Д.Каюмова

**ТИШЕКЛЕ́-ТОШЫКЛЫ** *с. к.* **тишек-тошыклы**. *Алга киткән милләтләр иске-москы чүпрәкләрен, тишеклетошыклы башмакларын да күргәзмәгә куя ---.* Г.Исхакый. *Яңа гына катып киткән кара җир өстенә әле юка, һич җаен табалмый килешсез генә яткан, ара-тирә тишекле-тошыклы кар келәмендә хозурланып кояш нуры бии.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ТИШЕ́К-ТИШЕК** *с.* Бик күп яки берничә тишектән гыйбарәт. *Кайчандыр тип-тигез булган бу ташлар, хәзер бөтенләй шадраланып, эчләре тишек-тишек булып ашалып беткән; тоткач, бармак арасында да уалып китәләр.* Гали Рәхим. *Табутның төбендәге такта тишек-тишек.* И.Салахов

**ТИШЕ́К-ТОШЫК** *җый. и.* **1.** 1) Һәртөрле тишекләр, ерык-ярыклар, ачыклыклар. *Икенче көнне дә кыр куяны Нуяк качар өчен тишек-тошык эзләп көн үткәрде.* Р.Батулла. *Нинди-дер уртак фикергә киленгәч, Силушкин старшина белән замполитка эндәште: – Рота дәресләрдә чакта бөтен тишек-тошыкларны, чардакны, кочегарканы, каптёркадагы чемоданнарны --- тикшереп чыгыгыз.* С.Шәрипов

2) *күч.* Җитешсезлекләр, нәрсә дә булса җитенкерәмәгән урыннар. – *Сөйләмә дә! – диде Хуҗи. – Теге «ярдәмче» сыерларны сатып-нитеп, кайбер тишек-тошыкны томаларбызмы әллә диген идем.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Һәртөрле тишекләр булган, ерык-ярыклар, ачыклыклар барлыкка килгән. *Беренче мәхәббәт чаткылары кабынган чакта, мин тишек-тошык киемнән, кызлар белән шаярасы урында, күбрәк дөнья мәшәкатьләре турында уйлый идем.* Ә.Рәшит. *Салам белән ябылган түбәләре тишек-тошык булса да, ишле мал торган абзарда җылы иде.* Н.Әхмәдиев

**ТИШЕ́К-ТОШЫКЛЫ** *с.* Тишек-тошыклары күп булган. *Тишек-тошыклы арбасын яман да калтырата-калтырата, юл тузанын куптара-куптара кайтып килә бу.* Ә.Баян. *Мин бу комбинатка директор булып килгәндә, тишек-тошыклы киемнәр гаять күп иде.* Р.Батулла

**ТИШЕЛЕШ** *и.* 1) Ашлыкның шытып чыгу процессы. *Нәфисә, --- кырга еш кына чыгып, бодай тишелешен күзәтә.* Г.Бәширов. *Шулай ук туфракны, игеннәр җыеп алынгач, көздән үк тирән сукалау җир катламы астына эләккән склероцийларның тишелешен тоткарлый.* Агулы үсемлекләр

2) *а.х.* Чәчелгән ашлыкның шытып, тишелеп чыгу ешлыгы; шытымның орлык бөртекләре санына нисбәте. *Белешмә графасына язганчы, кыз Вәзыйхка карады: «Саратовская–29»ның тишелеше 77 процент кына», – диде.* Х.Камалов. *Аннан соң пыяла шкафка урнаштырып, орлыкларның тишелешен тикшергәннәр.* Х.Садри

**ТИШЕЛЕШЛЕ** *с.* Тишелешендә билгеле үзенчәлек булган. *Үсешөлгереш чоры озынга сузылган, соң өлгерешле помидорлар, борыч белән баклажан, --- авыр тишелешле чәчәк орлыкларын нәкъ менә февральнең икенче ункөнлеге башында тартмаларга чәчү отышлы.* Мәйдан. *Чәчү алдыннан үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә барлык орлык та яхшы тишелешле.* Якты юл

**ТИШЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тишү**. *Балкага винт урыны тишелде.* Ф.Кәрим. *Шулай итеп, эреле-ваклы өч тишек тишелде, әмма берсе дә кызлар теләгәнчә үк килеп чыкмады.* Ф.Мөслимова

2) Нәрсәдә дә булса тишек барлыкка килү. --- *менә сиңа утын кирәк, өстеңә кирәк, түбәң тишелгән, аннан су үтә, балаңның аягына кирәк, хатынының пальтосы тузган.* Г.Бәширов. *Хатыннарның битләре корымланган,*

*тез турындагы оеклары тишелгән.* А.Гыйләҗев

3) Шытып чыгу, шыту; үсеп чыгу. *Арыш уҗымы тишелгән вакытта шәмәхә кызгылт була.* М.Мәһдиев. *Корыда озак вакытлар тишелә алмый яткан бөртек, дым булу белән шытып, үсеп киткән кебек, Гөлзаданың күңеле аңа карата кайнар хисләр белән тулды.* Ф.Садриев

4) *диал.* Борын төртү, борнау, күкәйдән чыгу (кош балалары тур.). *Артык түгел, ким түгел – Тишелеп чыктылар бүген Ун күкәйдән ун бәпкә.* К.Нәҗми

5) Шештән, чуаннан яки сызлавыктан эрен агып чыга башлау. *Шул вакытта ук шеш тулган булган икән, инде менә тишелде.* Н.Гыйматдинова. *Эренләгән чуан тишелмичә калмый бит...* Р.Юныс

6) *күч.* Беленү, билгеле булу; фаш булу, ачылу. *Көзлектә аның шул чуккасы үлде. Ләкин Әблиев аны суйган атлы итте дә мәктәптә --- завхоз вазифасын үтәүче егеттән район үзәгендәге ашханәгә тапшыртты. Авыл җирендә кемнең моржасыннан нинди төтен чыкканына хәтле билгеле булганлыктан, бу тишелде.* Р.Кәрами

**Тишелә бару** Торган саен күбрәк тишелү, булган берсе рәттән тишелү. *Соңгы көннәрдә явым-төшемнәр кыр эшләренә комачауласа да, моңа сөенергә генә кирәк: әүвәл чәчелгән участокларда орлыклар бик матур тишелә бара ---.* Безнең Чирмешән

**Тишелә башлау** Тишелергә тотыну; тишелү билгеләре күренү. *Әмма дошманнар ул алып кайткан байлыкның күп укылудан тишелә башлаган газета кисәге икәнлеген белмәгәннәр.* Ф.Яруллин. *Чиста ак күлмәгем бар, ә менә пинжәгем бик хөрти. Җиң очлары сүсәргән, җитмәсә, бер терсәге дә тишелә башлаган.* Идел

**Тишелеп бетү** Тәмам, бик нык тишелү; барысы да тишелү. *Врач Зарипов аңа каршы: – Әйе, аякка бастыра алмыйбыз, – диде, – әмма аны ул килеш ничек өенә озатасың? Ята-ята аркасы, янбашлары тишелеп беткән.* Ф.Яруллин. *Күлмәге белән чалбары таушалып-тишелеп беткән, йөзе кап-кара корымда.* З.Мәхмүди

**Тишелеп килү** Акрынлап, аз-азлап тишелү. *Әле күптән түгел генә утыртылган бәрәңге хәзер менә күпереп тишелеп килә.* Ф.Хөсни. *Кыярлар юньләп үсми, кишерләр дә авырлык белән генә тишелеп киләләр.* Татарстан яшьләре

**Тишелеп китү** Кинәт тишелү. *Җиргә сеңдек. Әгәр дә ярылса, тишелеп китсә, бу афәттән шунда кереп качуны мең тапкыр өстенрәк күрер идек.* Ф.Яхин

**Тишелеп чыгу** Бөтенләй, үтәдән-үтә тишелү. *Чалбарның тез башы тишелеп чыккан*

**ТИШЕМ** *и.* 1) Табигый яки махсус ясалган тишек. *Түгәрәк әйбернең яки әйбердәге тишемнең диаметрын кронциркуль ярдәмендә үлчиләр.* Физика

2) Тишексыман ачыклык. *Курайчылар да аны җыйганда, тишемнәр уйганда, белер-белмәс көйләренә байтак үлән курайны исраф итәләр.* Ф.Фәткуллин. *Озак та үтмәде, бораулап ясалган боз тишемендә чәбәләнгән балык башы күренде.* Ф.Имамов

**ТИШКӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тишкәләнү**. *Тояклардан тишкәләнгән чана эзен баһадир көпчәкләр тигезләде.* К.Кәримов

2) Күп урыннан һәм тәртипсез рәвештә тишелү. *--- ул тишкәләнгән казан өстен учы белән сыйпаштырды, --- казан астындагы сүнеп бетмәгән кисәүләрне алып аткалады.* Х.Камалов

**Тишкәләнеп бетү** Бөтенләй тишкәләнү; тәмам тишкәләнгән хәлгә килү. *Билендә исә таушалып, иләнеп, пычрап һәм утлы куз төшеп көеп, тишкәләнеп беткән күн алъяпкыч булыр.* Н.Фәттах. *Тишкәләнеп беткән эшләпәне күреп, артистлар дәррәү көлә башлый.* Р.Батулла

**ТИШКӘЛӘҮ** *ф.* 1) Күп җирдән, күп мәртәбә һәм тәртипсез тишү. *Муса йөзен кая яшерергә белми, кайнар ком бөртекләре битләрен инәдәй тишкәли.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Нәрсә яки кем турында булса да хәбәр җиткереп тору. *Укудан бушаган арада, күрше малайларына күзколак булырга күнеккән Надя Мироновнага карчыкларның тәртибе турында «тишкәләп» торды.* Р.Гаязетдин

**Тишкәләп бетерү** Тәмам тишкәләү, бик нык тишкәләү. *Абый, бу пирогны ни эшләп алай тишкәләп бетергәннәр?* А.Алиш. *Капчыкны чукып тишкәләп бетерерләр, өйалдына гына куйыйк.* Ф.Яруллин

**Тишкәләп тору** Әледән-әле тишкәләү яисә гел тишкәләү

**Тишкәләп чыгу** Барысын да рәттән тишкәләү. *Иске обойларны стенадан куптару өчен, башта махсус энәле валик белән йөреп тишкәләп чыгып, пар өрә торган җайланма белән дымландырырга мөмкин.* Кәеф ничек?

**Тишкәли башлау** Тишкәләргә тотыну

**ТИШКЕЧ** *и.* Көнкүрештә нәрсәне дә булса тишәр өчен кулланыла торган корал. *Остаханәдә балта, пычкы, тишкеч, өтерге, келәшчә, кыскыч, тагын әллә күпме кораллар бар.* С.Поварисов. *Ул машинасыннан чүкеч, тишкеч кебек кораллар алып кереп, стенага кадаклар какты.* Ф.Яруллин

**ТИШМӘН** *и.* 1) *диал.* Тишек ясау өчен кулланыла торган зур борау. *Тишмән белән бүрәнә тишү*

2) *зоол.* Катыканатлылар отрядыннан агачны ашый-ашый юллар ясап, тишкәләп бетерә торган озынча гәүдәле кечкенә коңгыз; *русчасы:* **жук-сверлильщик**

**ТИШҮ** *ф.* 1) Тишек ясау; тишек барлыкка китерү. *Авыл тирәсендә дистәгә якын скважина гына тиштеләр.* А.Тимергалин. *Шуннан бер ай чамасы үткәч, төнлә өйләренә кайтып килгән чагында, артыннан таш җибәреп, Ханәфинең башын тиштеләр.* В.Нуруллин

2) *күч.* Сер булырга тиеш, сөйләргә ярамаган нәрсәне кемгә булса да әйтү, белдерү. *Бабай кычкырып елап җибәрде: – Сөйләмә, остазбикә, карчык бәддогасы... – дип, елап, кайгысыны тиште.* Г.Исхакый. *Чит кешегә әйтеп булмый, беркемгә дә сөйләмәскә ипи тоттырып ант иттергәннән соң, бу хакта ул үзенең хатынына тиште.* Ф.Садриев

**Тишә бару** Эзлекле рәвештә бер-бер артлы тишү

**Тишә башлау** Тишәргә тотыну. *– Тауны тишә башласаң, су фонтан*

*булып ургылып чыгачак та авылны юып китәчәк икән, – ди.* М.Яһудин. *Мин сандык төбендәге бер тишекне фанер кисәге белән кагып та куйган идем, күрәсең, тычкан яңа тишек тишә башлагандыр.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тишә язу** Чак кына тишми калу. *Латыйфи буе белән безне сокландырмакчы булып үрә баскан иде, баш түбәсе түшәмне тишә язгач, лып итеп урынына утырды.* М.Хуҗин. *Ә менә үзе аткан чөгендере, өч мәртәбә кире тәгәрәп, аның башын тишә язды.* Ф.Садриев

**Тишеп бару** Тоташтан, рәттән тишү

**Тишеп бетерү** Барысын да тишү; тәмам, нык тишү. *Чалбарымны ертып, ботинка табаннарымны тишеп бетердем.* А.Хәсәнов. --- *тишек-тошык лапас стеналарыннан учма-учма тулы ай нуры эчкә үтеп керә дә, каралып, корт тишеп бетергән иске бүрәнәләргә төшеп уйный.* Х.Мөдәррисова

**Тишеп карау** Тишергә тырышу, тишергә омтылыш ясау; тишеп тикшерү. *Я, подполковник, маңгай белән стенаны тишеп кара инде!* Г.Әпсәләмов. *Алар бер-бер артлы геолог Зәйнуллин белән күрешеп чыктылар. --- Сөйләшә торгач, тегермәнче ничектер бик серле итеп: – Тишеп карадыгызмы соң әле, Зәйнуллин иптәш? Ничегрәк? Булырлыкмы? – диде.* Н.Фәттах

**Тишеп кую** Алдан тишү; тишекле итү. *Көне билгеләнгәч, ул --- Рөстәм машинасының дүрт тәгәрмәчен дә тишеп куярга әмер бирде.* К.Кара. *Шуннан соң кесәсеннән нәни пәкесен ала да алма салырга дип бирелгән сумканың төбен тишеп куя ---.* Т.Нәҗмиев

**Тишеп тору** Әледән-әле тишү яисә гел тишү

**Тишеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр тишү; һәрберсен бер-бер артлы тишү

**ТИЮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә бәрелеп туктап калу яки шундый торышта булып алу; икенче бер әйбергә кагылу, орыну яки терәлү. *Тешләре тешкә тимәгән, бөтен гәүдәсе калтырап торган Газига җылыну өчен бик ярап куйды ул йөгерү.* М.Хәсәнов. *Бәхете бар икән мескен болан баласының. Аз гына түбәнгә йөзеп, тояклары чак-чак кына каты җиргә тиюе була, бер-ике талпынуда ярга эләгә.* С.Шәрипов

2) Берәр ноктага яки чиккә җитеп терәлү. *Күпме вакыт йомшак урынҗир күрмәгән һәм тәмам хәлдән тайган Фәгыйлә башы мендәргә тию белән изрәп китә, күз кабаклары авырая, татлы йокыга тала башлый.* С.Сабиров. *Малай башы түшәмгә тигән зур суыткыч, матур шкафлар куелган иркен кухняда авыз эченнән көйли-көйли йөренде.* Р.Фәизов

3) Атылып, очыртып җибәрелгән нәрсә билгеле урынга эләгү, туры килү. *Снарядлар танкның берсе бер ягында, икенчесе икенче ягында шартлады. Өченче снаряд танкның нәкъ алдына тиде.* Х.Камалов. *Шулай да бертуктаусыз атылган йөзләгән укның берсе арысландай сугышкан Анагыр ханга барып тиде.* Р.Сәгъди

4) Төзәлгән ноктага килеп, шул нокта урынын җимерү, тишү; яралау яки үтерү (ук, пуля, ярчык һ.б. тур.). --- *бомба туп-туры йортка тимәгән, ул берничә метр гына читкәрәк төшеп шартлаган, ләкин шулай да почмакны актарып ташлаган.* Ә.Еники. *Аждаһага тимәгән уклар гөнаһсыз адәмнәрнең башына төшмәсен.* Р.Батулла

5) Зарар итәрлек берәр нәрсә төшү, сугу. *Малайлар белән уйнаганда, шары белән тисә, барысын да аяктан ега торган була.* Әкият. *Чүкеч тиеп авырттырган бармагын суырып торган Илдар --- энесенә күтәрелеп карамады.* Г.Гобәй

6) Ток тәэсир итү. *[Яшь чакны искә төшерү] Мортазинга юеш тәнгә электр тогы тигән кебек тәэсир итте.* Г.Әпсәләмов

7) Аз гына ягылу, буялу (буйый, пычрата яки ашый, ачыттыра, яралый торган нәрсәләр тур.). *Мин бер генә өйне күрдем. Ишегаллары капкасыз, йөзлегенә буяу тимәгән тәрәзәләре җирдән хәтсез биектә.* К.Кәримов. – *Син, килен, нигә шул хәтле тутырып карыйсың? Әллә битемә корым тигәнме? – дип уңайсызланып калды, бит очлары тагын да алсуланыбрак киттеләр.* Гөлшаһидә

8) Зыян китерү, зарарлау; бераз пычрату (корткыч бөҗәкләр, гөмбәчекләр һ.б. тур.). *Буй җитмәслекләре дә бар алмаларның. Андыйлар, үз тиңнәрен көтә-көтә, алмагачында кортлый. Корт тимәгәннәре көзенә кадәр агачында кала.* З.Мәхмүди. *Күнгә көя тигән*

9) Җигелгән хайванның дирбияләре җайсыз ятып, аның тиресен җәрәхәтләү, чиләндерү. *Сөякләр итсез тирене шулай тиз тишеп чыгалар икән. Колхозда ябык атларга да шулай камыт тия, муеннарын чиләндерә торган иде.* Х.Камалов. *Ат ябыкса, аңа һәрвакыт камыт, ыңгырчак тия торган була.* Ф.Галиев

10) Кемне дә булса кул белән җәберләү, кыйнау-сугу; кемгәдер һөҗүм итү. *Кызга тимәгән, ягылмаган, бары чын күңелдән сөйләшергә генә теләгән.* Х.Камалов. *Без аның белән бик ныклап сөйләштек инде, курыкма, энем, тимәс. Әгәр ялгыш кына кул тидерсә дә, килеп, Мәдинә апаңа әйт.* В.Нуруллин

11) Берәр нәрсәгә рөхсәтсез кагылу, аны алырга омтылу. *Хәзер инде төрлетөрле тавышлар яңгырый: – Тимә минем мендәргә... – Үз мендәрең белән сугыш...* С.Поварисов. *Нинди коралга тотынсам да «тимә» дип әйтүче булмады.* Ф.Яхин // Берәр нәрсәдән рөхсәтсез файдаланырга тотыну, урлап ашау. *[Шәмси:] Күмәчләрен инде калдырып китсәм, песи-мазар тияр микән?* М.Фәйзи. *Малга бүре тия, салам вә игенне бик урлыйлар.* Г.Ибраһимов

12) Урлау яки талау. *Биредә ат караклары яшәгән, алар халыкныкына тимәгән, әмма дәүләтнекен үзенә кирәгенчә басып алганнар.* Ф.Бәйрәмова. *Иптәшләре белән кибетчене бәйләп салып, кыйнап, кибетен талап чыкканнар. Минем малай сукмаган да, әйберенә дә тимәгән, барыбер судья ышанмады.* И.Сираҗи

13) Кабып карау; тату. *Шул инде, аз гына аракыга авызы тисә, нишләгәнен белми.* Х.Камалов. *Азгын сыерларны, авызы ашлыкка бер тисә, сумаладай ябышып кала торган сарыкларны көтүдә чыбыркысыз тыям димә.* Н.Әхмәдиев

14) Сәламәтлеккә зыянлы тәэсир итү. *Авылда шундый көчле радиация булгач, ничек соң сиңа тимәгән ул?*

Ф.Бәйрәмова. *Максут хатыны Кәшифә апаны аңсыз килеш район хастаханәсенә алып киткәннәр, уф, үпкәсенә суык тигән.* Г.Якупова

15) Нинди дә булса берәр нәрсәнең билгеле бер тәэсире (файда яки зыяны) булу. *Менә шулай бәхетле генә яшәп ятканда, Таңсылуның әбисе авырып киткән: тамагына ашамаган, төннәрен йокламаган. Докторлар чакырып караганнар – аларның да ярдәме тимәгән.* Ф.Яруллин. *Без урнашкан өйгә янгын тимәгән.* Ф.Сафиуллин

16) Өлешенә туры килү, эләгү, тиеш булу; насыйп булу. *Сыек шулпа һәркемгә берәр касә генә тиде.* А.Хәсәнов. *«Күгәрчен сөте» дигән романына һәм шул ук тышлыкка сыйган хикәяләренә гонорар алгач, малаена велосипед бүләк итмәкче иде ул, мәрхүм. Ләкин велосипедка җитәрлек тә акча тимәгән.* Ф.Баттал

17) Билгеле бер урын, мөмкинлек, форсат һ.б. булу. *Иркенләп сөйләшергә вакыт тимәгән иде, менә хәзер генә икәүдән-икәү калдылар, Гайнан аңа сугышчан бишлекләрне оештыруның барышы турында тулырак сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Билалов, шушы арада гомуми җыелыш үткәрергә кирәк, дигән фикергә килде. Силушкин командир булганнан бирле, нигәдер форсат тими.* С.Шәрипов

18) Көтмәгәндә, очраклы рәвештә нindидер уңайлылык туры килү. *Милиционерлар тыз-быз чаба, Президент парахутына ук утыру бәхете тимәгән эреле-ваклы җитәкчеләрнең күзләре Кабан күленә төбәлгән.* Т.Миңнуллин

19) Билгеле бер кардәшлек бәйләнешендә булу. *Ул безгә әллә әткәй, әллә әнкәй ягыннан кардәш тия.* Г.Әпсәләмов. *Аның Аннасы безгә туган тия.* М.Хуҗин

20) Нәрсәнең дә булса эшен туктату, гамәлдән чыгару, бетерү яки тәнкыйтьләү. *Әгәр дә иске советка тимичә, яңасын сайласаң?* И.Гази. *Хөкүмәткә тимә син, диде, аның нигезе какшарлык түгел, карт имән чересә дә тамыры ньк була, диде, аның кулында армия, банк, телеграф, аның кулында каратель органнары, диде.* М.Хәсәнов

21) *диал.* Башлыча *кебек, кук, шикелле* сүзләре яки *-дай/-дәй, -тай/-тәй* кушымчалы сүзләр белән килеп, «тоелу» дигән мәгънәне аңлата. *Күктә якты-якты йолдызлар күп. Иң яктысы син күк тиясең.* Ш.Маннур. *Балаларга мәктәп ишек алды чирәмендә җыелышу кызыграк тиеп китте.* Г.Бакиров

22) *күч.* Психикага, күңелгә һ.б.ш.га начар тәэсир итү. *Егетнең сүзләрендә дә, кыланмышларында да янында торган хатыннарны баласыту, үртәү ярылып ята – бигрәк тә шунысы күңелгә тия иде.* М.Маликова. *Дистәләрчә күзләр карап торганда, кәкре кабырга хәтле хатынның йодрык селтәве шофёрның мин-минлегенә тиде.* Ф.Яруллин

◊ **Тисә – кошка, тимәсә – бушка** *к.* **тисә – тияккә, тимәсә – ботакка**. **Тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка** *к.* **тисә – тияккә, тимәсә – ботакка**. *Тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка – бу безнең принцип түгел.* Г.Әпсәләмов. *Аппаратта әллә ниткән «помеха»лар бар иде, шуларның берсендә «бугазы» дигән сүз дә ишетелгәч, Әркәшә, тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка, дигәндәй, Аллага тапшырып, беренче тотылган шифрограмманы ачты.* М.Мәһдиев. **Тисә – тиенгә, тимәсә – куянга** *к.* **тисә – тияккә, тимәсә – ботакка**. *Аларга «штурмовщина» вакытында, тисә – тиенгә, тимәсә – куянга, дигәндәй, тагын да өстәнрәк бирелгән күрсәтмәләрне үтәргә генә кирәк.* И.Гыйләҗев. **Тисә – тияккә, тимәсә – ботакка** Эшнең телләнчә килеп чыгуына игътибар итмәү, нәтиҗәсен уйламау турында. *Ул, мулланың сүзе бетәр-бетмәс, күзләрен төшереп, йөзен җитдиләндерде дә, берәр минут уйлаганнан соң, Җаббарның күзенә шелтәле бер караш ташлады: – Мулла Җаббар агай, сез һәрвакыт «тисә – тияккә, тимәсә – ботакка» дигән кебек сөйлисез.* Г.Ибраһимов. **Тисә – тиенгә, тимәсә – тияккә** *к.* **тисә – тияккә, тимәсә – ботакка**. *Фатыйма карчык аңа тагын бертын карап торды да, тисә – тиенгә, тимәсә – тияккә, дигәндәй, әйтеп куйды ---.* М.Кәбиров. **Тия керү** *к.* **тия узу**. *Хәсәен абзый, авылыңа үтешли тия кер.* Һ.Такташ. **Тия узу** Юлда, берәр җиргә барышлый, узышлый кемгә булса да кереп чыгу, кагылу. *Китәр алдыннан Алексейга тия уз. Ул синең белән авылдагы эшләр турында сөйләшергә тели.* К.Нәҗми

**Тиеп алу** Кыска вакытка, тиз генә тию. *Шунда аның иреннәре ханымның колак яфракларына тиеп алды, кыска итеп киселгән чәчләре битен кытыклады.* Ф.Яруллин. *Бурзай, ни микән бу диптер инде, иң элек боз кебек салкын борыны белән моның шәрә тәненә тиеп алган ---.* Ф.Садриев

**Тиеп карау** Тиергә тырышу. *Безнең кызларга тиеп карасын, арт сабагын укытырбыз!* Р.Хәбибуллина. *Ә караучысыз калган товарларга ник берәрсе тиеп карасын!* Ф.Мөслимова

**Тиеп китү** Аз гына тию. *Кортларыбыз канаты тиеп киткән һәр үлән, һәр чәчәк сафлана, яшәрә, серкәләнеп, яшәреп кала.* А.Хәсәнов. *Шытып килгән яшь үләннәргә кулы тиеп киткәч, башыннан әтисе сыйпап куйгандай булды.* Н.Хәсәнов

**ТИЯК** I *и.* 1) Элмәк кидерү өчен аркылы агач. **---** *өй эче, аның бар почмаклары, идән, түшәм ярыклары, тәрәзә яңаклары, таш келәтне хәтерләткән алгы якның чөйләрендәге вак-төяк төенчекләр, --- сугым элә торган тиякләр, бер сүз белән әйткәндә – һәрнәрсә яңа, әле генә пешеп өлгергән яшь, беренче бәрәңгенең күңел кылларына кагыла торган әчкелтем-төчкелтем рухияте белән сугарылган иде.* А.Хәлим // Берәр үзәккә, кендеккә һ.б.га беркетелгән махсус келә, аркылы таяк яки рычаг. *[Буровойда] яңа вахтаны хезмәт урынында каршылыйбыз дип торганда, элеваторның тияге сынып чыкты.* Г.Ахунов

2) Кармак сабындагы алка. *Сары Пышлак торды, ыштанын каккалады, кармак таягы белән тияген иелеп алды.* Ә.Гаффар

3) *иск.* Төймә урынына кулланыла торган озынча агач яки сөяк кисәге. *Муенга элмәк – тияккә ялау.* Әйтем. *Һәр кыяташ, һәр сөякле тияк, Һәр тамчы су монда кансырый.* Ф.Гыйззәтуллина

**ТИЯК** II *и. диал.* 1) Атларның яше һәм җенесе ягыннан беришле аерым төркеме өчен махсус көтүлек. *Ат*

*әйләнеп тияген табар, су әйләнеп улагын табар, ир әйләнеп илен табар!* Р.Батулла

2) *күч.* Туган җир, туган туфрак. *Табынганы – Күк – Тәңредер, Очар коштыр, Сагынганы – туган тияктер... Бу дөньядан аңа берни кирәк түгел, Ул дөньяга, бәлки, кирәктер.* Г.Морат. *Зыянчура тиягендәге Байдәүләт авылын, Сүрәм елгасын сагынып кайткан-да, кызыкай, авыл баласы булып, бер кинәнеп яшәп ала.* Сөембикә

**ТИЯР** *и.* Кертелгән хезмәт өчен алачак өлеш. – *Бай бул, олуг хан! – диде базарган, бишкә бөгелеп. – Калганнарын чыгарып тор, иртәгә көн яктысында карармын, – диде Алмыш хан. – Тияре турында да шунда сөйләшербез.* Н.Фәттах. --- *үзең үстергәнне үзең тапшырасың, чөгендер кабул итү пунктына үзең төяп озатасың һәм тияр әҗерен дә үзең аласың.* Г.Якупова

**ТИЯ́Р-ТИМӘС** *рәв.* Кагылыр-кагылмас, орыныр-орынмас. *Ботаклары җиргә таба тартылып торган карасу чыршыларның түбәләренә тияр-тимәс кенә булып күзгә авыр болытлар агыла.* Г.Әпсәләмов. *Кара тәреле самолётлар нарат башларына тияр-тимәс кенә очып йөрделәр.* М.Мәһдиев

**ТМИН** *и. яһүд. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан ак, ал яки кызыл чәчәкле, эфир майларына бай орлыклары тәмләткеч буларак кулланыла торган әчкелтем хуш исле ике яки күпьеллык үләнчел үсемлек; шул үсемлекнең орлыгы; әнеч; чыпчык көпшәсе. *Бәрәңге, чөгендер, кишер, суган, помидор, кыяр утырткан. Кориандр, әнис, борыч, тәмәке, тмин, – тагын әллә ниләр чәчеп бетергән.* М.Галиев

**ТОБА** *и.* **1.** 1) Елга, күл һ.б. сулыкларда аеруча тирән урын, упкын, чоңгыл. *Ялтырап яткан Идел өстен чуарлатып, салмак кына саллар ага. Тирән тобаларга, чоңгыл урыннарга көймәләре белән балыкчы бабайлар утырганнар ---.* Т.Гыйззәт. --- *ятьмә белән сөрә-сөрә, Хәсән тобасы түбәндәге утырык комлыкны әйләнеп узгач, инешнең шуннан соңгы тарайган, --- ургылыплар торып аккан төшенә җиткәндә, ул --- ятьмәсен тотып, тымызыграк урыннарны --- сөзеп баручы Тимерче Сөләйманнан беркавым аерылып торды.* Ә.Гаффар

2) Бик тирән табигый чокыр. *Хәтерлисеңме, сине текә ярдан тобага чөймәкче идем. Миннән озаттырмаганың өчен.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Тирән. *Ваем төбе тоба су, батарсың да китәрсең, Тәвәккәллек – көймәдер, ишәрсең дә кичәрсең.* Мәкаль

**ТОБАЛЫ** *с.* Тобасы яки тобалары булган. *Иж сулары тирән, бик тобалы. Әйләнәсе аның тал-тирәк.* Т.Гыйззәт. *Башта, егет белән очрашкач, аның коты очкан иде, ул курку әле дә йөрәктә бар, текә яр һәм томырылып аккан тобалы елга кара сурәт булып күз алдында чайкала, ләкин курkуның көче кимегән саен кими, кимегән саен кими.* Н.Гыйматдинова

**ТОВАР** *и. төрки* 1) *икът.* Алмашу, сату, сәүдә әйләнешенә кертү өчен җитештерелгән әйбер, продукт

2) Көнкүрештә кирәкле һәм сатыла торган әйбер, сатыла торган мал – сәүдә предметлары. *Сәүдәгәр шәһәрдән товар алып кайтып, шуны сатып көн күрә.* Әкият. *Сууре Яани халкы шәһәрчә киенә, кибетләрендә киң куллану товарлары, хәтта бу көннәрдә бөтен СССРда җитешмәгән сөлге, оекбашлар да тулып ята.* Т.Әйди

3) Сәүдә, җитештерү һ.б.ш. максатлар белән берәр урынга озатыла торган йөк. *Мөһаҗирләр һәммәсе исән-сау килеш Казанга барып җиттеләр һәм, берничә товар вагонына төялеп, Одессага юл тоттылар.* М.Галәү. *Товар поездына паровоздан соң ук тәрәзәләре тимер рәшәткәле өч вагон тагылган була, аларның баштагы икесе зэклар өчен, ә иң соңгысы арестантларны озата баручы каравыл өчен икән.* А.Тимергалин

4) Сатыла торган продукциянең аерым төре. *Бакчага кирәк-яракны кайтарып бетергәч, алар Кашкарый белән хуҗалык товарлары кибете янына китәләр.* М.Маликова. *Киләсе елга авыл хуҗалыгы товарларына бәя арту мөмкин.* Г.Галәметдин

**ТОВА́Р ӘЙЛӘНЕШЕ** *и. икът.* Товар сатылып, шуның акчасына башка әйбер җитештереп, сатуга чыгару. *Илләр арасында экономик тотрыклылык нык сизелә башлады. Товар әйләнеше елдан-ел үсә.* А.Хәсәнов. *Узган елны ике арадагы товар әйләнеше 4,6 миллион доллар булган.* М.Вафин

**ТОВАРЛАНУ** *ф.* 1) Товарга әверелү

2) *сөйл.* Күп итеп товар алу. *Яльчик базарыннан товарланып кайттым әле*

**ТОВАРЛАШТЫРУ** *ф.* Сәүдә әйләнешен реаль товар белән тәэмин итү, акчаны товарга әйләндерү. *Ярый әле безнең акча күп түгел, тегене-моны алырлык кына. Соңгы көннәр дип, рупияләр, пайсларны Тибет базарында «товарлаштырдык».* М.Мәһдиев. *Ай башында тасма итеп бирелгән талоннарны «товарлаштыру» өчен, ярмасына, итенәмаена, хәтта балалар колготкиена чират торулар дисеңме.* Шәһри Казан

**ТОВАРЛАШУ** *ф.* Товарга әйләнү; товар белән тәэмин ителү

**ТОВАРЛЫК** *и.* **1.** Товар буларак югары кыйммәтлелек; сату өчен яраклылык. *Базарда сыерлар күп булган, ә алырга атлыгып тормыйлар икән. Безнең сыер тирәсендә йөрүчеләр күп. Тик малкайның «товарлыгы» юк: мөгезләр сугып төшерелгән, койрык кисек, янбаш янтайган...* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Товар итеп сатылган яки сатылырлык; ихтыяҗ тудырырлык. *Агач кәүсәсен, тамырын һәм ябалдашын механик, механик-химик һәм химик юл белән эшкәртеп, товарлык материаллар җитештерелә.* Төзү материаллары. *Шул ук вакытта товарның кулланылышта булмавы, товарлык кыйммәтен югалтмавы, пломба, ярлык кебек әйберләре саклануы шарт.* Әгерҗе хәбәрләре

**ТОВАРЛЫКЛЫ** *с.* 1) Товар итеп сатылырлык, үтемле, базарлыклы. *Сәламәт сыердан гына сәламәт бозау, югары товарлыклы продукция алырга була.* Р.Исмәгыйлова. *Алты айда нефть-газ-химия комплексы буенча товарлыклы продукция сату күләме 245,9 миллиард сум --- тәшкил иткән.* Ватаным Татарстан. *Товарлыклы әйберләр. Товарлыклы культуралар*

2) Сату өчен җитештерелә торган. *Сату өчен товарлыклы йөзем үсте-*

*рүдән тыш, алар үзләре өчен дә еллык яшелчәсен, җиләк-җимешен әзерли, терлек тә асрый.* Т.Әйди. *Аерым алганда, көненә 100 тонна товарлыклы сөт җитештерү, 100 тонна ашлык үстерү, шикәр чөгендере игүгә йөз тотып эшләргә кирәк.* Кайбыч таңнары

**ТОВАРОВЕД** *и. рус* Товарларның үзлекләрен һәм аларның сатылучанлыгын билгеләүче белгеч. *Тимерша абзый кулланучылар җәмгыяте карамагындагы кибеттә сатучы, аннары Казан җиһаз фабрикасы филиалы Келәүштә товаровед була.* Н.Гыйматдинова. *Мин институтны бетереп, шәһәребез сәүдә базасында товаровед булып эшли башладым.* Л.Таналин

**ТОВАРЧЫ** *и.* 1) Товарлар белән эш итүче хезмәткәр яки сатучы. *Анда да алга китәрлек эш күренмәгәнгә, кышын вак товарчы булып сатуга тотынды.* Г.Исхакый. *Элек, сугыштан соңгы елларда, безнең авылда да самавыр төзәтүчеләр, итек басучылар, вак товарчылар, алма сатучылар, кырыктартмачылар шулай сөрән салып уза торганнар иде.* Р.Батулла

2) *к.* **товаровед**

**ТО́ГА** *и. лат.* Борынгы Рим ир-атларының өс киеме – киң плащ. *Мәрмәр идәнле кечерәк бер залның уртасында 40–50 яшьлек ир-ат басып тора. Ул яшел каймалы ап-ак тога кигән, башында бер чәч бөртеге дә юк.* А.Шәйхин

◊ **Тогасына төрену** Үзеңне нинди дә булса атаклы, зур кеше итеп күрсәтергә тырышу. *Галим тогасына төренү. Герой тогасына төренү*

**ТОЕК** *и.* Төрки халыклар поэзиясендә аллитерацион (гадәттә 4–6 юллык) шигырь. *Борынгы төрки шигырьдә берничә мәгънәгә ия булган адаш сүзләр белән рифма ясауны тоек дип йөрткәннәр.* Н.Исәнбәт. *З.Мансур --- борынгы чичәннәр поэтикасында кулланылган тоек алымын уңышлы куллана.* Н.Юзиев

**ТОЕЛУ** *ф.* 1) Сизү органнары белән кабул ителү. *Бит очлары алсулана, бөтен тән буйлап кайнарлык йөгерә, җиңелчә рәхәт арыганлык тоела.* Г.Бәширов. *Яланаякка су башта салкын тоелды.* Н.Фәттах

2) Билгеле бер эш-хәрәкәткә, билгегә һ.б.ш. нәрсәгә охшатып кабул ителү. *Алардан чыккан тавыш машиналардан чыккандай тоела.* А.Алиш. *Хәсәнгә имән өстәл дә йомшак ястык кебек тоелды.* А.Расих

3) Субъектив рәвештә (чынлыктагыдан зуррак яки кечерәк, матуррак яки ямьсезрәк һ.б. булып) кабул ителү. *Мәрьямгә агачларның яфраклысы чагыштыргысыз матуррак тоела иде.* М.Маликова. *Опера театры мин көткәнгә караганда кечерәк тоелды.* Ф.Яруллин

4) Билгеле фикер тудыру, билгеле тәэсир ясау. *Минем гомумән аракы эчмәвем аңа бик сәер тоелды бугай, колакларына ышанмыйча, беравык гаҗәпләнеп карап торды.* С.Сабиров

5) Күзаллану, уйланылу. *Язгы иртәләрдә, кун сумкасын асып, кыр юлына чыкса, тургайлар җырын ишетсә, каршысына Әптерәй кайтып килер төсле тоела иде.* Г.Сабитов

6) *з.-сыз* Үзеннән-үзе сиземләнү, сизелү. *Сынауларын бирә алмыйча хур булыр төсле тоела.* Ф.Яруллин. *– Кайчан да булса бер очрашырбыз кебек тоелса да, биредә үк булыр дип уйламаган идем, – диде ул, кызның кулыннан әйберләрен алып.* Г.Бәйрәмова

**Тоела башлау** Бер-бер хәлдән яки күпмедер вакыттан соң башкача булып тоелу. *Хәзер миңа Фатыйма белән Әркәнәй карчык өрәк булып түгел, нахакка җәберләнгән мескеннәр булып тоела башлады.* Г.Бәширов. *Тора-бара бу мәҗлес кызыксыз һәм мәгънәсез тоела башлады ---.* А.Гыйләҗев

**Тоелып китү** Кинәт кенә тоелу; кыска вакытка, азга гына тоелу. *Хәтта бер корымланган кисәктән төтен исе килгәндәй тоелып китте.* А.Тимергалин. *Зөһрә Фатыйма карчыкка үз киленедер сыман тоелып китте.* М.Кәбиров

**Тоелып тору** Хәзер, шушы вакытта яки һәрвакыт тоелу. *Сизелеп-тоелып тора: Кәшһәк ханбикәгә ярарга тырыша, чама хисен югалтканын да сизми ахры.* М.Әмирханов. *Ләкин кызыгы шунда: Нурихан абый үзе булмаса да, аның рухи энергетикасы Дәрвишләр бистәсеннән үк сизелеп, тоелып тора иде.* Б.Рәхимова

**ТОЕМ** *и.* Нинди дә булса нечкәлекләрне тою, сизү сәләте. *Ниндидер бер эчке тоем, булмә эчендәге аерым бер яктылык, биткә килеп бәрелгән җылылык моның шулай икәнлеген әйтеп тора иде.* Ф.Яруллин. *Бала баккан аналарда гына була торган тоем, сизем аңа, йокы чиген үтеп, эчкәрәк керергә, онытылырга ирек бирми иде.* Г.Гыйльманов

**ТОЕМЛА́У** I *ф.* 1) Бераз тою, сизгерлеге булу. *Авыртуны тоемлау*

2) Тоярга тырышу; чамалау, сиземләү. *Ошбу каршылыклы тойгылар, курәсең, аның тормышчан гадилегеннән, үз чорын тирәннән сөреп, аңлап, киләчәкне тоемлап, иҗатында шуның чаткыларын чагылдырып кала алу сәләтеннән килә торгандыр.* И.Гыйләҗев

**Тоемлап алу** Тиз арада тоемлау. *Сөләйман паша ризалыгын бирә бирүен, әмма ханның хәйләсен бик тиз тоемлап ала.* М.Әмирханов. *Җитәкче кешенең эшкә карашын коллектив бик тиз тоемлап ала.* Шәһри Казан

**Тоемлап кую** Кинәт, бер тапкыр тоемлау. *Шулай да соңгы җыры яңгыраганын һәр тамашачы сизде, Салават та тоемлап куйды ахрысы.* А.Шәймәрдәнов

**Тоемлый башлау** Нәрсәнедер тоемлау барлыкка килү. *Ул үзенең кеше икәнлеген беренче тапкыр менә шушында кабат тоемлый башлады.* Ф.Яхин. *Аның аяк бармаклары селкенә, чеметкәләп алуларны тоемлый башлый.* Иделем акчарлагы

**ТОЕМЛА́У** II *и.* Тою, сизү халәте; сиземләү хисе; интуиция. *Сабые йомшак иреннәре белән күкрәккә орынуга, үзеннән балага сулкылдап яшәү көче агылганын тоемлау гына калды, аргы яктан чытлыкланып көлешкән тавыш ишетелмәс булды.* М.Маликова. *Чыннан да, моңа кадәр хәвеф-хәтәрдән исән чыгуларында Мөнирҗанның табигый тоемлавы, оста манёврлары роль уйнамый калмагандыр.* Н.Әхмәдиев

**ТОҖРАЙТУ** *ф. диал.* Күзләрне зур итеп ачу, акайту. *Иманкол хаҗиның өлкән хатыны --- күзләрен тоҗрайтып, яшел бизәкле алъяпкычына битендәге эре бөрчекле тир тамчыларын сөртә.* К.Нәҗми. *Күзләрен тоҗрайтып,*

*Нурмөхәммәт килеп керде.* С.Кудаш. *Алар бит Рәсәй тарафларыннан килгән хатын-кызга аеруча каныгалар, күзләрен тоҗрайталар да, кайда мөмкин, шунда тозак куеп, эзәрлекләргә тотыналар ---.* А.Хәлим

**ТОҖРА́У** *ф. диал.* Күзләр зур итеп ачылу, акаю. *Әлтаф абзыйның күзләре тоҗрый, ялт-ялт карана башлады.* Н.Исәнбәт

**ТОҖРАЮ** *ф. диал. к.* **тожрау**

◊ **Тожраеп калу** Гаҗәпләнүдән, аптыраудан озаклап карап тору. **Тожраеп кату** *к.* **тожраеп калу**

**ТОҖЫ** *с. диал.* **1.** 1) Чиста, пакь, ару. *Бу көймәнең --- иң матур, төзек, бик тоҗы саналган беренче урыны [әйбәт].* Шура. *Тоҗы йорт*

2) Матур, пөхтә. *Тоҗы киемле кыз*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшы, матур итеп. *Тоҗы тору*

2) Бик чиста, бик җыйнак, пөхтә итеп. *Тоҗы киенү*

**ТОҖЫМ** *и.* 1) Үрмәкүч пәрәвезенең көз көннәрендә һавада очып йөри торган бик нечкә җепселе. *Ә бу пәрәвез көз көне һавада оча торган юка җеп – тоҗым гына түгел шул инде...* Х.Ширмән. *Октябрь башында да, әбиләр чуагындагы кебек, сукаланган басу өсләрендә тоҗым җепләре уйнаклый иде әле.* В.Гали

2) Ике багана яки терәк арасына тарттырылган аркан, тимерчыбык, бау һ.б.ш. *Тоҗым сузу. Тоҗым тарттыру*

**ТОҖЫР** *с. диал.* Зур итеп ачылган. *Тоҗыр күз*

**ТОҖЫ́Р-ТОҖЫР** *рәв. диал.* Бик зур булып, бик зур ачылып. *Күзләре миндә [еланның] – яна тоҗыр-тоҗыр.* Н.Исәнбәт

**ТОҖЫРУ** *ф. диал.* 1) Эшләү, эш чыгару, берәр эшне җиренә җиткереп башкарып чыгу, булдыру. *Мужик сәнәгенә калсаң, бернәрсә дә тоҗырып булмый...* М.Галәү. *– Замполит, алай булмый, аны тоткарламагыз! – дип кычкырды Черняев. – Нигә булмасын? – Турыга барып ни тоҗырасың? – Мин дә турыга дип әйтмим.* Х.Камалов. *Малайларым бик әллә ни тоҗырырлык булмасалар да, хатын сайлый белделәр анысы: киленнәрем икесе дә акыллы, тырыш.* Шәһри Казан

2) Эшлекле, белдекле булып күренеп, эшне бозу. *– [Машиналар] дүртәү генә булган ла! – Тоҗырган икән [тәэминатчы]! – диде Гушанов.* Ш.Бикчурин

3) Куып чыгару. *[Апаң] ничәмә-ничә яшь журналистны редакциядән кудырды бит... Мине дә шулай тоҗырмакчы.* А.Гыйләҗев. *Өйдән тоҗыру. Эштән тоҗыру*

4) Майтару, кыру. *Ну, нәрсә тоҗырасың болай йөреп?*

**ТОЗ** *и.* 1) Ашамлыкны тәмләү өчен кулланыла торган ак кристалл рәвешендәге минерал. *Бервакыт без, шаярып, кызларны көлкегә калдыру өчен, тегеләр күрмәгәндә генә, боткага күп итеп тоз салдык.* Х.Камалов. *– Соңгы тапкыр, – дип пышылдады һәм Асафны суырып үпте – егет аның кабарынкы ирennәрендә исерткеч тоз тәмен тойды ---.* М.Мәһдиев

2) *хим.* Гадәти шартларда суда эри торган ионлы төзелешле кристаллар рәвешендәге химик кушылма төре. *Экспедиция Карабугаз култыгын өйрәнеп, тирәнлекләрне үлчи һәм аның төбендә глаубер тозы ятмалары барлыгын ача.* Фән һәм тел. *Ашказаны, эчәк авыруларыннан сихәт бирә торган «Ижевск» минераль сулары хлорид, сульфат катнашмасына һәм кальций, натрий тозларына бай.* Ватаным Татарстан

3) *күч.* Сүзгә, нотыкка эчтәлек үткенлеге бирә торган төп фикер, төп мәгънә. *Корыган агачның суты, мәгънәсез сүзнең тозы булмас.* Мәкаль. *Сәлим мәҗлесләрне бик ярата. Ләкин үзендә булсын, кешедә булсын – исерә, сүзенең тозы юк, җырының көе юк.* Казан утлары

◊ **Тоз сипкәннәр** Кешеләрне күпләп үзенә тарта торган урын турында. *Әнә, урып җыюны тәмамлауны сәбәп итеп, кәеф-сафа корырга ашкынган кайбер агайлар, хәзер уңга-сулга карамыйча, Үгез Салихы йортына элдертәләр генә, малай. Тоз сипкәннәрмени, көннәр буе шунда яталар.* И.Диндаров. **Тоз ялаткандай** *к.* **тоз сипкәннәр**. *Комсомол җыелышы буласы көн җиттеме, тоз ялаткандай, Әптери гел шул тирәдә бөтерелә.* Ф.Хөсни. **Тоз өстенә торма** «Кайгы өстенә кайгы, борчу өстенә борчу» мәгънәсендә әйтелә. *Бу хәл [Зыяның авыруы] аның анасына тоз өстенә торма дигәндәй тәэсир итә.* Г.Ибраһимов

**ТОЗАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **тозландыру** (*2 мәгъ.*). *Җиһангир --- кемгә күзен тозайтырга белгән.* Г.Мөхәммәтшин

**ТОЗАК** *и.* 1) Кыргый кош-киекләрне тоту өчен, аларның муенына яки аягына уралырлык итеп куела торган ятьмә, җеп, тимерчыбык һ.б.ш.дан гыйбарәт ау. *Урман аланы тиздән кошларның өзгәләнеп кычкырган авазы белән тулган: – Бер кисәк иткә алданып, тозакка эләктек, – дип каркылдашкан каргалар.* Әкият. *Алар арасында энә-җеп, уймак ише вак нәрсәләр, без, хәтта шөшле, урак, пычак, хәнҗәр, кайчы, йозак, ау тозаклары, сызгыра торган ук башлары --- һәм башка әйберләр бар иде.* А.Тимергалин

2) *күч. хәрби* Төрле яшерен юллар белән оештырылган камау, камалыш, чолганыш; шуннан гыйбарәт тактик алым. *Җиһангир, --- чиксез кыюлык белән һөҗүм итте, чигенде, тагын һөҗүм итте, ә гитлерчылар, бер-бер тозакка эләкмәс өчен, --- вак төркемнәргә бүленмичә, тәртипсез атаата, юлларын дәвам иттерделәр.* Г.Әпсәләмов. *Иң башта килә торган танк та, тезмә юлдан читкә тайпылып, арты белән яртылаш сазга чумып бара. Мостафинның эченә җылы керде: мин аларны шушы тозакка эләктерер өчен чигендем, дип акланырга була хәзер.* Х.Камалов

3) *күч.* Кемгә дә булса зарар китерү өчен, алдан уйланылган хәйләлемәкерле гамәл. *Атаң белән кайнатаң ул арада сиңа әллә кайчан тозакны корып куйган, --- ришвәтләр бирә-бирә, тамга җыйган була.* Г.Ибраһимов. *Ләкин Б.Гайсиннан качкан Хәләф тиктомалдан гына икенче бер тозакка килеп капты. Ул баскычтан ах-вах килеп өске катка күтәрелгән Рауза ханымга килеп бәрелде.* Х.Ибраһим

**ТОЗАКЛЫ** *с.* 1) Тозак куелган; тозак белән эшләнгән. *Тозаклы юл. Тозаклы ау*

2) *күч.* Мәкерле, хәйләле

3) *күч. сир.* Бикле, тыелган. *Дилең [күңелең, акылың] өчен телең булсын*

*тозаклы.* Дәрдемәнд. *Күңелебез тозаклы, телләребез йозаклы, дигәндәй, безне кемнәр күрсеннәр дә кемнәр белсеннәр?* Т.Гыйззәт

**ТОЗАКЧЫ** *и.* 1) Тозак кулланып киек тотучы кеше. *Тозакчы үзе күренмәс, җимен генә күрсәтер.* Мәкаль

2) Тозакны эшләүче яки төзәтүче

**ТОЗГЫ** *и. тар.* Кадерле кунакларны каршы алганда тәкъдим ителә торган ипи-тоз, кыйммәтле бүләкләр һ.б.

**ТОЗКҮЗ** *и.* Оятсыз, әдәпсез, тотнаксыз. *Малик кебек тозкүз ыржаеп торганда, нинди сөйләшү булсын ди.* Д.Гыйсметдин. *Теге тозкүз Шагали түгел микән? Җәй көне аның Фаягөл янына туктап, мут күзләрен майландырып сөйләшеп торганын күргәннәр.* Ф.Абдуллин

**ТОЗЛАВЫК** *и. к.* **тозлак 1.** (*1 мәгъ.*)

**ТОЗЛАК** *и.* 1) Коры далаларда, чүлләрдә тозлы су кипкәннән соң тупланып калган тоз ятмасы. *Израильнең мактанычы булган Үле диңгез дә ел саен бер метрга саегып бара һәм тиздән тозлакка әйләнәчәк.* А.Тимергалин. *Һуннарның җирләре, кулләрдән һәм тозлактан гыйбарәт булып, утрак тормышка яраксыз.* Фән һәм тел

2) Туфракның коры зоналарга хас, гумуска ярлы, балчыклы, тозлы төре. *Янә урыны белән тозлак (солончак) яки катыр (солонец) туфрак төрләрен дә күрергә була.* А.Фәткуллин. *Тозлак үсемлекләре бергәлекләре коры климатлы өлкәләрнең түбәнлекле урынnarында һәм диңгез буйларында формалаша.* Физик география

3) *бот.* Алабутачалар семьялыгыннан икеҗенесле чәчәкле, чүлләрдә, ярымчүлләрдә, тозлы туфракта үсә торган берьеллык үлән, куак, ярымкуак яки ярымкуакчыл үсемлек; *русчасы*: **солянка**. *Ярымчүлләрдә һәм чүлләрдә тәбәнәк әрем, кылган, тозлаклар үсә.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТОЗЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тозлану**. *Туфракны тозландыру*

2) *күч.* Оятсыз рәвештә туп-туры карау. *Мин булачак ирем янына кунакка киләм, ә ул, авызына су капкандай, бер сүзсез күзен тозландырып карап тора.* Р.Вәлиев

**Тозландырып бетерү** Бөтенләй, тулысынча тозландыру

**ТОЗЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тозлау**. *Ара-тирә борынга җир исе килә: имән урманындагы көзге җир имән мичкәдә тозланган ак гөмбә исен бәреп утыра.* М.Мәһдиев. *Гөмбә янына тозланган помидор белән сало да туралган иде.* Р.Гаязетдин

2) Үзенә тоз сеңү, тоз утыру, тоз белән аралашу. *Кайвакытларда шундый янарга-пешәргә туры килә, гимнастёркалар тозланып ката.* Г.Кутуй. *Бик пөхтә итеп чөйгә элеп куелган теге ямаулы --- чалбарын һәм аркасына астар тегелгән (бусы арка тире белән тозланып тиз тузмаска) күлмәгенең тузанын кагып, әкрен генә киенде.* Ә.Гаффар

3) Гомумән тоз белән катнашу, составындагы тоз күләме арту. *Аның күз яшьләре тамган җирдә үләннәр көйгән, гөлләр каралган, чишмәләр тозланган.* Ф.Яруллин. *Һашим учына аккан күз яше белән әзрәк тозланган суга иреннәрен тидерде.* Т.Гарипова

**Тозлана башлау** Тозлану билгеләре сизелү. *Яшәүчеләр шулай ук соңгы вакытта артык тозлана башлаган суга зарландылар.* Ютазы таңнары

**Тозланып бетү** Тулысынча, бөтенләй тозлану. *Ардуанов, грузчик заманнарда тозланып беткән иске фуражкасын кулында йомарлап, әртилчеләренең сүзен тыныч кына тыңлый ---.* Г.Ахунов. *Уй-хатирәләргә батып, җылытырга куйган ашын оныткан түгелме! Кайный торгач кыркуланып, тозланып беткәндер.* Р.Камалетдинова

**Тозланып җитү** *к.* **тозланып бетү**

**Тозланып тору** Тозланган хәлдә булу

**ТОЗЛА́П-БОРЫЧЛАП** *рәв.* 1) Тоз һәм борыч салып. *Кеше көченнән тамак туйдырып, Бәлешләр ашап тозлап-борычлап [мулла йөри].* М.Гафури. *Вәзир бу юлы да тозлап-борычлап пешерелгән тел алып килгән.* М.Әмирханов

2) *күч.* Бик ачы, үткер, тәэсирле итеп; көчле тәэсир итә торган сүзләр кыстырып. *Ә хәзер бар, ике-өч битлек кенә фельетон язып китер. Тозлап-борычлап яз, мәчет җылый, дип провокация таратучы обывательләрнең авызын томаларлык булсын.* Ә.Еники. *Тозлап-борычлап түйганчы сүгенде, Замир ягына явыз итеп карап: «Син нәрсә, мине миңгерәү сарык дип беләсеңме?»* Т.Галиуллин

3) *күч.* Җиренә җиткереп, тиешенчә, шәп итеп. *Мортаза! Мин бу ел рабфакны тозлап-борычлап тәмам итәм.* Һ.Такташ. *Кичә каты сугыш булды. Немецларны тозлап-борычлап пешердек.* Г.Кутуй

**ТОЗЛА́У** *ф.* 1) Ашамлыкка тәм кертү өчен тоз кушу, тоз салу. *Еш кына лекцияләрдән шулхәтле ачыгып кайтабыз, бәрәңге пешкәнне көтәргә сабырлык җитми, суганны турыйбыз да, үсемлек мае белән аш серкәсе сибеп, нык кына тозлап, кара ипи белән сыпырабыз гына.* М.Маликова. *Әлеге дә баягы бер түшкә каз янына тозлап пешерелгән карт тавык, ике дистәләп «каты» күкәй, ике түгәрәк ипи, шешә белән сөт, банкасы белән каймак, яшелчә, алма белән груша...* Р.Гаязетдин

2) Нәрсәнең дә булса өстенә тоз сибү. *Бер олы кайнар бәрәңгене алып, мул итеп тозлап, авызын тутырып капты.* Ә.Еники. *Пешкән кукурузны тозлап ашыйлар, тәмле...* Р.Кәрами

3) Берәр нәрсәне, озак вакыт саклаганда черемәсен, бозылмасын, кортламасын өчен, вак тоз белән аралаштыру, тоз сибү, тоз сеңдерү, тозлы суда тоту. *Бу авыллар заманында гөр итеп йорт сырасы, сало ясап, гөмбә тозлап, --- әйләнә-тирәдәге татар белән әвәрә килеп яшәгәннәр дә Бөек Ватан сугышыннан соң кинәт егәрсезләнеп калып бушаганнар.* М.Мәһдиев. *Ашап-эчеп бераз кәефләнеп алгач, алар икәүләп балык тозларга керештеләр.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Нәрсәне дә булса озак файдаланмыйча яткыру, озак үзендә тоту яки кирәкмәгәнгә саклау, кулланмау. *Ул, йөзе кара, минем бер предложениене өч ай буе кесәсендә тозлап йөртте-йөртте дә хәзер, кайбер үзгәртүләр белән, үзенеке итеп эшләгән.* Г.Кутуй. *Ул дипломны тозлап куймаслар бит инде, быел бирмәсәләр, икенче елны бирерләр.* З.Мәхмүди

5) *күч. к.* **тозлап-борычлап** (*2 мәгъ.*). *Мин синең хатыныңа тозлап, тәмләп хат яздым.* Р.Батулла

6) *күч.* Бармыйча, кермичә калу; ташлап, качып китү. *Шушы сәгать ярым вакыт эчендә моңа кадәр бу картның лекциясен «тозлап» йөрүемә үкенеп утырдым.* Л.Ихсанова. *Йоклый-йоклый лекция язып, көчкә түзеп утырасың да: «Болай булмый», – дип, калган парларны «тозлап», өйгә кайтып авасың.* Р.Газизуллина

**Тозлап алу** Бераз тоз тидерү

**Тозлап бетерү** Тозлау эшен тәмамлау. *Бабай, әбекәй, кыярны тозлап бетердегез дәме әллә?* А.Хәйретдинова

**Тозлап җибәрү** Тиз генә тозлау; аз гына тозлау. *Кыярын, гөмбәсен, кәбестәсен тозлап җибәрәләр – телеңне йотарсың.* Д.Салихов

**Тозлап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә тозлы итү

**Тозлап карау** Булу-булмавын тикшерү-сынау өчен тозлау. *Алдан ук әйтеп куябыз: тозлы карбыз һәркемнең дә күңеленә хуш килмәскә мөмкин. Шуның өчен башта 1–2 банка гына тозлап карагыз.* Сөембикә

**Тозлап кую** Алдан ук яки тиз генә тозлау. *Алдагы атнада, базардан алып кайтып, берәр чиләк кыяр тозлап куярга кирәк.* М.Мәһдиев. *Мин инде чормага әллә ничә пот балык тозлап куйдым.* Ф.Яруллин

**Тозлап тору** Даими, һәрвакыт тозлау; хәзерге моментта тозлау; тозланган хәлдә тоту. *Балыкны алдан бераз тозлап торуны Аяз абый үзе өйрәтә ---.* Б.Рәхимова

**Тозлый башлау** Тозларга тотыну. *Кыяр-помидор тозлый башласа, бөтен дөнья банкалар белән тула.* Сөембикә

**Тозлый төшү** Тозны гадәттәгедән артыграк салу; беркадәр тозлау

**ТОЗЛУТ** *и. бот. к.* **тозлак** (*2 мәгъ.*). *Тозлы яки тозланган туфрак өсләрендә, һәрвакыт диярга ярый, тоз яратучы үләннәр – тозлутлар (солянкалар) үсә.* А.Фәткуллин

**ТОЗЛЫ** *с.* **1.** 1) Үзендә тоз эрегән, тозы булган яки тоз салынган. *Фәниярның суга өйрәнмәгән тәне өши, ләкин барыбер дулкыннар кочагыннан чыгасы килми. Авызга, борынга тозлы су тула, сулыш кысыла, әмма рәхәт.* Ф.Яруллин

2) Тозы артык салынган. *Фу, бәлешең тозлырак булган түгелме?* А.Гыйләҗев. *Иң беренче итеп, күпләр тарафыннан сыналган чара – ашың тозлы, дип бәйләнде.* Ф.Яруллин

3) Саклау өчен тозланган, тозлап куелган. *Хәят тавыш-тынсыз гына киенеп чыгып китте һәм ун минуттан тозлы балык алып кайтып, кискәләп куйды.* Ф.Садриев. *Ул үзенең булдыксызлыгыннан гарьләнә, пешекче кыз янына буш кул белән кайтырга ояла, шулай ук складтагы тозлы итне алырга да хурлана иде.* Р.Вәлиев

4) Тозлап әзерләнгән. *Анда, баз уртасында, зур мичкә белән тозлы кәбестә утыра.* З.Зәйнуллин. *Күршеләрнең кыш буе өстәленнән тозлы кыяр, тозлы кәбестә, тозлы гөмбә өзелми.* Н.Гыйматдинова

5) *күч.* Үтемле, үткер, тәэсирле. *Аннан үзенең нинди хәвефтән исән-имин калуын аңлап булса кирәк, бер тозлы сүз әйтте.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Артык кыйбат. *Туфлинең --- хакы да бик тозлы икән.* С.Рәфыйков

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Нык тәэсир итәрлек, көчле итеп. *Татлы хыялларым шундук бүленде: акай күз, тозлы гына итеп, минем борынга берне кундырды.* Чаян

◊ **Тозлы су** Күз яше. **Тозлы су агызу** Елау, балавыз сыгу. *Болай булгач шатланырга, көләргә кирәк, ә ул, тинтәк кыз, елый. Күзеннән тозлы су агыза.* Ф.Хөсни. **Тозлы су сипкәннәр** *к.* **тоз сипкәннәр**. *Соң, читтә ялгыз башыңа рәхәт кенә бит, нигә кайтасың, ни калган сиңа монда, әллә тозлы су сипкәннәрме?* С.Поварисов. *Өйдән кеше гел өзелеп тормады. Тозлы су сипкәннәр, диеп уйларсың.* Р.Гаязетдин

**ТОЗЛЫ́-БОРЫЧЛЫ** *с.* 1) Тоз, борыч һ.б. тәмләткечләр кушылган

2) *күч.* Бик ачы, үткер; көчле тәэсир итә торган. *Аларның тозлы-борычлы сүзләре Иван колагына да килеп иреште.* Р.Батулла. *Уло кырыс, җитди яза, Юриның хикәяләре һәм повестьлары исә шактый ук тозлы-борычлы, халыкчан юмор белән сугарылган ---.* Т.Әйди

**ТОЗЛЫК** *и.* 1) Яшелчә, балык, уылдык һ.б.ш.ны тозлау өчен, тоз эретелгән су, тоз эремәсе. *Иртән Глаша капчык сыман гимнастёркадагы үзенең көтелмәгән бәхетен кызганып куйды, аңа кыяр тозлыгы эчерде.* Ә.Мушинский. *Диабет белән авырганда, тозлы кәбестә тозлыгына бераз гына лимон суты салып эчү файдалы.* Сәламәт булыйк!

2) Итле аш өресеннән ясалган соус. *Арзанлы итнең тозлыгы татымый.* Мәкаль. *Ит белән эш тәмам булгач, кастрюльдән кружкаларына шулпа салып, шуны ашыкмыйча гына эчәргә тотындылар. Казакъча әйтсәк, бу тозлык та бик тәмле-үткер иде.* Ә.Еники

**ТОЗЛЫЛЫК** *и.* Тозлы булу; тозлы булу дәрәҗәсе. *Бәрәңгене сөт белән кушып ашагач, тозлылыгы әллә ни сизелмәде тагын.* Г.Галиева. *Диңгез-океан суларының тозлылыгы һәм температурасы төрлечә була.* А.Тимергалин

**ТОЗСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тозны бик аз салып яки бөтенләй салмыйча әзерләнгән. *Тозсыз ашның нинди тәме булсын?* К.Миңлебаев. *Ул арада тозсыз пешерелгән ипи килеп җитте, төче коймак пәйда булды, су китерделәр...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Мәгънәсез, ятышсыз, урынсыз яки әдәпсез (сүз, шаяру, кыланыш һ.б.). *Тагын бер тозсыз җыр яңгырады.* М.Мәһдиев. *Телләрдә тозсыз мәзәкләр. Мәзәкләр оятсызрак булган саен, көлеш көчәя.* Ф.Яруллин. *Силушкин соңгы вакытта бераз җитдирәк, кырысрак йөри, тозсыз кәмитләрен дә киметте.* С.Шәрипов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тоз салмыйча, тоз кушмыйча. *Мин хәзер тозсыз ашамыйм бит, Гөлфинур.* А.Вергазов

2) Тоздан башка. *Тик менә тозсыз ничек яшәрбез?* Р.Сәгъди

**3.** *и. мәгъ.* Мәгънәсез сүз сөйләүче, ямьсез кыланучы кеше. – *Син әллә кайчан өйләнгәнсеңдер, балаларың үсеп җиткәндер инде. – Синең хәтлеләр. – И тозсыз!* М.Хуҗин

**ТОЗСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Эчәргә яраклы итү өчен яки техник максатларда, суны эрегән тозлардан арындыру, чистарту. *Чаллы ТЭЦында суны термик тозсызландыру технологиясе белән эшли торган икемаксатлы деаэратор гамәлгә кертелде.* Ватаным Татарстан. *Монда төче суны, нигездә*

*җайланмалар ярдәмендә, диңгез суын тозсызландырып алалар икән.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Мәгънәсезгә, әһәмиятсезгә әйләндерү. *Әлбәттә, һәр эштә чама кирәк. Артык тозлап җибәреп тозсызландырырга да ярамый.* Ш.Галиев

**Тозсызландырып җибәрү** Бераз, берникадәр тозсызландыру. *Фәкать муллалар сценасы, кирәгеннән артык көлү илә мәзах вә һөҗҗүдән чыгып, тәхкыйрь дәрәҗәсенә килеп җитеп, хикәяне бераз тозсызландырып җибәрмештер.* Г.Камал

**ТОЗСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Тозы юкка чыгу

2) *күч.* Мәгънәсез, урынсыз сүз сөйләү яки кылану, шаярту. *Бәхтиярның ачуы йөзенә чыкты, кунакның әдәпсезлеге өчен оялгандай: «Тс-с, алай ярамый, зинһар, тозсызланма», – дип туктатты һәм капканы ачарга кушты.* С.Сабиров. *Нәзилә үз итеп кенә иренең аркасына суккалады: – Ярар инде, Рәсим, тозсызланма, өйдә ашатмыйлар икән кияевемне, дип уйлар әнкәй, – дип куйды.* А.Әхмәтгалиева

**Тозсызлана башлау** Тозсызлану билгеләре сизелү. *Экологлар, диңгез суы тозсызлана башлаган, дип хәвефләнә*

**ТОЗСЫЗЛЫК** *и.* 1) Тозсыз булу; тозы булмау, тозы җитәрлек булмау. *Имам кискән икмәкне сындырып авызына капты, чәйни башлады һәм аның тозсызлыгына төшенде.* Ә.Сәлах

2) Төче тәм килү. *Рөстәм иртәгесен --- авызында бер тозсызлык тоя.* С.Җәлал

3) Тоз булмау; тоз кытлыгы. *Сугыш елларында халыкны тозсызлык тилмертте*

4) *күч.* Мәгънәсез, ятышсыз сүзләр куллану, урынсыз шаярту. *Менә бу безнең драма әсәрләребезнең «тозсызлыгын», «чиле-пешле» икәнен күрсәтә.* Т.Гыйззәт. *– Сез ирегезне бик яратасызмы? – Без ятатышып өйләнештек... – дип җавап бирде Илсөяр, сорауның тозсызлыгына гаҗәпләнеп.* Ә.Сафиуллин

**ТОЙГЫ** *и.* 1) Эчке тоем; нәрсәне дә булса сизеп алу, интуиция. *Вахит, үз күңелендәге тойгыдан котыла алмыйча, җаен табып, тукталыш будкасын урап-әйләнеп чыкты. Кем белә, бәлки, аның таныш эте шушы тирәдә йөридер?..* Г.Гыйльманов. *Ишекне ачып керүгә үк, миңа сәер бер тойгы иярде, шул тойгыга буйсынып, йокы бүлмәсенә ташландым.* А.Әхмәтгалиева

2) Хис. *Син аны мәхәббәт, сөю тойгылары белән исерткәнсең. Ярату тойгысы көчле булганга күрә ахры, мин аны бөтен тәнем, рухым белән җырладым.* Г.Кутуй. *Син, шул матур тойгыга бирелеп, көне буе гаҗәеп бер җиңеллек хис итеп йөрисең, гүя күңелеңдә кояш нуры уйнап тора.* Г.Әпсәләмов // Билгеле бер мөнәсәбәткә яки билгеле бер рухи халәткә хас булган кичереш. *Алар шулай --- элегрәк бик үк сизелмәгән якынлык, туганлык тойгысы белән, Яңавылның яртылаш чирәм баскан киң урамыннан бардылар ---.* Н.Фәттах. *Ялгызлык тойгысы көчәйгән саен, Ләйсирәне ныграк сагына, катырак көтә иде.* М.Вәлиев

**ТОЙГЫЛЫ** *с.* 1) Ниндидер тойгыларга бай; ниндидер тойгылар белән сугарылган. *Шагыйрәләрнең беришесе кичереш үсешен, хисне үзәккә алса, икенчеләре тойгылы фикер агышына өстенлек бирергә мөмкин.* Т.Галиуллин. *Аның җыры артыгы белән тойгылы, артыгы белән авыр иде.* Ф.Яхин

2) *лингв.* Өндәү (җөмлә тур.) *Тойгылы җөмләләрне Г.Алпаров, беренче буларак, өндәү термины белән атый.* Татар грамматикасы

**ТОЙГЫЧАН** *с.* Тойгыларга, хисләргә бирелүчән, хисчән. *Ризванның яшь, тойгычан күңеленә бу юлдан язганнар --- мәңге онытылмаслык җәрәхәтләр ясадылар.* А.Расих

**ТОК** *и. рус* Электр корылмасы агымы; электр энергиясе. *Үзенең төзелеше белән моторга охшашлы генераторның эчендә ток хасил булыр.* А.Алиш. *Лагерьны ураган тимерчыбыкларга ток тоташтырылган.* Г.Әпсәләмов

**ТО́КАРЬ** *и. рус* Металл, агач һ.б.ш. материалларны махсус кискечләр, кыргычлар ярдәмендә кырдырып эшкәртүче. *Солтан белән бергә алар яшь чакларында токарь булып эшләделәр.* Г.Әпсәләмов. *Хәтта бер япон кызы, аңа тиешле детальне бик төгәл итеп ясап биргәч (мин, хәрби заводта эшләгәндә, югары разрядлы токарь идем), --- яңагымнан да үпкән иде.* М.Хәбибуллин

**ТО́КАРЬЛЫК** *и.* Токарь булу, токарь эше, һөнәре. *Авылда чакта ук тимер белән бераз таныш булуым ярдәм итте, күрәсең: слесарь агай --- мине токарьлык эшенә – станокка күчереште.* Х.Туфан. *Ул, --- токарьлыкка өйрәнеп, пенсиягә чыкканчы заводта эшләде, үзенә үзе хуҗа булды.* М.Хуҗин

**ТОКЛЫ** *с.* Үзендә ток булган. *Шәһәрне кош та очып керә алмаслык биек таш коймалар урап алган, аларның өстеннән электр токлы чыбыклар үткәрелгән.* Ф.Бәйрәмова. *Хәмит, токлы урындыкка утыргандай, калтыранып китте.* Җ.Дәрзаман

**ТОКМАЧ** *и.* 1) Ашка салыр өчен, җәймәне озынча итеп вак-вак кисеп ясалган камыр эшләнмәсе. *Кунада ике җәймә токмач камыры әзерләнеп куелган.* М.Хәсәнов. *Коймак та пеште, чәй дә эчтек, Гүзәлия бик нечкә итеп токмач кисте ---.* М.Мәһдиев

2) Шул вак-вак камыр кисәкләре салып пешерелгән шулпалы аш. *Гадәттәгечә, кибеттән кайтуга, аш, ягъни токмач, өстәлгә менде.* К.Тинчурин. *Аннары, тын калып, итле токмач капкаладылар.* Х.Камалов

**ТОКМАЧЛЫ** *с.* Токмач салып пешерелгән. *Башта күкәйгә басылган токмачлы аш бирделәр, аннан соң пешкән бәрәңге белән ит бирделәр, чәй бирделәр.* Н.Фәттах. *Менә хәзер дә, уттай янган башын су белән чылатып, кояшта уйнаган тамчыларны күзәтә, үзенең күз алдында токмачлы шулпа белән кара арыш ипие.* Х.Ширмән

**ТОКМАЧЛЫК** *с.* **1.** 1) Токмачка ярарлык, токмач ясауга китә торган. *Токмачлык он да бетеп килә икән.* Сөембикә

2) Билгеле бер күләмдәге ашка җитәрлек. *Бер токмачлык кына итем бар, малай кайтса дип саклаган идем.* Т.Гарипова

**2.** *и. мәгъ.* Токмачка дип билгеләнгән нәрсә. *Токмачлыкны әзерләп кую*

**ТО́КСИК** *с. биол., мед.* Агулый торган, зәһәр. *Токсик элементлар, пестицидлар, микотоксиннар һәм башкаларның*

*икмәк-күмәч эшләнмәләрендә гигиена нормаларына туры килмәве 0,11 процентны тәшкил иткән.* Мәйдан. *Авыр металл һәм куркыныч токсик матдә булып саналган кадмий кеше организмында бавырда һәм бөерләрдә җыелып бара.* Ватаным Татарстан

**ТО́КСИКЛЫК** *и.* Токсик булу сыйфаты; агулылык дәрәҗәсе. *Токсикологик тикшеренүләрнең бурычы булып, тире антисептикларының токсиклыгы дәрәҗәсен ачыклау һәм аларны куллану куркынычсызлыгын нигезләү санала.* Йолдыз

**ТОКСИКО́ЛОГ** *и. гр.* Токсикология белгече. *Татарстан токсикологиясе тарихында беренче мәртәбә Россиянең баш токсикологы Н.Остапенко җитәкчелегендә алдынгы токсикологлар да җыелачак.* Казан утлары

**ТОКСИКОЛО́ГИК** *с.* Токсикологиягә караган, токсикологиягә бәйләнешле. *Профессор Н.М. Догель үз хезмәтләрендә алкоголь куллануның медикпсихологик, токсикологик һәм тулы социаль анализын ясый.* Кәеф ничек?

**ТОКСИКОЛО́ГИЯ** *и. гр. мед.* Медицинада агуларның физик һәм химик үзлекләрен, аларның тере организмга тәэсирен һәм агулануларны дәвалауны өйрәнә торган тармак. *Мәгълүм булганча, бүгенге чорда иң зур ачышлар төрле фәннәрнең бер-берсенә тоташкан ноктасында ясала. Шуңа күрә ул фармацевтиканы да, токсикологияне дә нык өйрәнде.* М.Маликова. *Ашыгыч ярдәм өлкәсендәге әйдәп баручы белгечләр терапия, травматология, токсикология --- һәм башка юнәлешләр буенча --- кичектергесез ярдәм күрсәтү мәсьәләләре хакында фикер алышачак.* Казан утлары

**ТОКСИКОМАН** *и. гр. мед.* Агулы матдәләрне исерткеч буларак файдаланууга иялләнгән, токсикоманиядән интегүче кеше. *Бензин парын сулап алганнар. Ну нишлисең – токсикоманнар! Килеп җитте болар ава-түнә. Җиргә ятып сулыш алдылар.* Аманулла. *Күз яшем белән елый-елый --- барлык корылмаларны җимереп ташларга туры килде. Чөнки минем бизәлгән чишмәмне шәһәрнең токсикоманнары күреп алганнар.* Казан утлары

**ТОКСИКОМА́НИЯ** *и. гр. мед. к.* **токсикоманлык** (*2 мәгъ.*). *Хәзер инде тәмәкене аны кызлар да тарта. --- Чөнки тәмәке тарту эчкечелек, токсикомания, наркомания кебек куркыныч күренешләр янында чүп кенә булып калды.* Р.Миңнуллин. *Менә шул культура сарайларының бөтенләй булмавы яки булып та халыкка тиешенчә хезмәт күрсәтмәве наркоманиягә, токсикоманиягә (авыл җирендә), эчкечелеккә этәрүче төп фактор булып әверелде.* К.Сатиев

**ТОКСИКОМАНЛЫК** *и.* 1) Токсикоман булу

2) Төрле агулы әйберләрне исерткеч буларак кулланырга теләк уята һәм организмның функцияләрен боза торган авыру, чир. *Бары тик мәктәп белән гаилә бердәм булып, кулга-кул тотынышып эшләсә генә, наркоманлык, токсикоманлык кебек яман чирләрдән котылу җиңелрәк булачак.* Татарстан яшьләре

**ТОКСИН** *и. гр. мед.* Кайбер микроорганизмнар, шулай ук кайбер хайваннар һәм үсемлекләр бүлеп чыгара торган агулы матдә. *Арпа организмны токсиннардан һәм шлаклардан чистарта, эчәкләрне дәвалый һәм организмны шикәр чиреннән саклый.* Шәһри Казан

**ТОК-ШО́У** *и. ингл.* Иҗтимагый, сәяси һ.б.ш. мәсьәләләр турында җәмәгать эшлеклеләре, белгечләр һәм башка затлар катнашында үткәрелгән фикер алышу һәм шул рухта әзерләнгән телетапшыру. *Телевидениегә безнең күптөрле кызыклы тәкъдимнәребез бар: кызыклы тапшырулар, ток-шоулар оештырырга мөмкин булыр иде.* Р.Вәлиев. *Тормыш дәрәҗәсе аска тәгәрәгән чорда телевизор әйтерсең лә икенче бер дөньяда яши: анда гел бәйрәм, җыр, ток-шоулар, уен-көлке.* Д.Гыйсметдин

**ТОКЫМ** *и.* 1) Хайваннарның нәселдән килгән билгеле сыйфатлары, үзенчәлекләре белән үз төреннән аерылып торган группасы; *русчасы*: **порода**. *Ни хикмәттер, токымы шундыйга күрәме, башкорт аты, әйтик, немец яки хохол атларына караганда, бәдәнгә кечерәк тә, арыграк та, әмма инде чыдамлылыгына исең-акылың китәр!* Ә.Еники. *Израиль галимнәре йонсыз тавыклар токымы китереп чыгарган.* Т.Сабирҗанов

2) *сөйл.* Гомумән җан иясе төре. *Кырыла бүре токымы, кырыла.* Р.Батулла. *Әйдә, балакай, чанаңны мондарак китер, икәү күтәреп салмый булмас: яңа туган булса да, авырлыгы җитәрлек моның, ат токымы бит...* Г.Галиева. *Эт токымы гомер бакый адәм баласына тугрылыклы хезмәт итте.* З.Мәхмүди

3) Бер бабадан килә торган нәсел вәкилләре, кардәш-ыру. *Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде: барыбер аның токымы ич, аның каны!* Ә.Еники. *Хәмидулла токымы корырга түгел, җиргә нык басып, таза тормышта яшәргә исәпли иде.* Р.Батулла

4) Тумышы-чыгышы белән нинди дә булса аерым бер катламга, социаль төркемгә караган затлар, кешеләр. *Гомере буе эчмәгән-тартмаган, тапканын саклап торткан, шуның аркасында гына ватанында «кулак токымы» дип тинтерәтелгән газизләренә булыша алган ул.* Т.Әйди. *Милләт язмышы монда гасырлар дәвамында формалашкан, асылда татарның зыялы катламын тәшкил иткән морзалар токымы тарихын яктырту ярдәмендә чагылдырыла.* А.Әхмәдуллин

5) Билгеле заттан, төрдән һ.б. калган дәвамчы буын. *Миннән татар токымы калмаячак, марҗаныкы йотачак.* Н.Әхмәдиев. *Каяндыр, очраклы рәвештә барлыкка килмәгән, без – борынгы һәм данлыклы халык токымы.* Ш.Баһаутдин

6) *геол.* Җир кабыгы катламнарының билгеле бер төре; казылма минерал. *Буровой көнне-төнне белми, гөлдер-гөлдер, дөбер-шатыр килеп эшли, ә әрсез борау каты тау токымын кимерә, җимерә башлады.* З.Мәхмүди. *Эшләгәндә, бер метр да егерме сантиметр биеклектәге таш токымы астында калып, тилмереп, күзгә карап ятучылар, гарип калучылар булды...* Татарстан яшьләре

◊ **Токымын корыту** Берәр нәсел, зат вәкилләрен тәмам юкка чыгару. *Татыр җәзасы, татыр көннәре алда ул имансызның. --- Менә әйткән иде дияр-*

*сең, аһ-зарым барыбер Ходай Тәгаләгә барып җитәр. Каргышым токымын корытыр, боерган булса.* М.Хәсәнов. *Шаһ Гали мокыт нәчә тапкыр кулга төште, ас-кис, токымын корыт иде...* Р.Батулла

**ТОКЫМДАШ** *и.* 1) Бер милләттән яки тамырдан булган нәсел вәкиле. *Менә сина теләк-васыятьләрем. Иң беренче, үзеңнең --- татардан икәнеңне онытма. Вә икенчедән, бел: синең каныңда татар биләре, тарханнардан килгән Дым-Су ага. Ә тарханнар --- шул ук ханның токымдашлары, бер тамырдашлары.* Р.Сибат. *Шулай берчак токымдашлары Мөхәммәдне нык кына кысалар: пәйгамбәр булсаң, могҗиза кыл, Гайсә пәйгамбәр шикелле телсезне – телле, чулакны – куллы, сукырны күзле ит...* Г.Хөсәенов

2) Башкасы белән бер үк төр хайваны, төрдәш хайваны

**ТОКЫМЛА́У** *ф.* Токым буенча аеру, аерымлау. *Атларны токымлау*

**ТОКЫМЛЫ** *с.* Яхшы яки махсус токымнан булган. *Шулар янында фрауның токымлы мүкләгә биргән сөт һәм өйдә ясаган татлы чөгендер сиробы да бар.* А.Тимергалин. *Моны күреп торган Пират – бүре токымлы, безгә яхшы таныш урман кыргый җанвары – Мәскәү этенә сикерде.* З.Хөсни яр

**ТОКЫМЛЫЛЫК** *и.* Токымлы булу; саф канлылык. *Җирле нәселле атлар белән эш итеп булмый, нәкъ менә токымлылыкка басым ясарга кирәк*

**ТОКЫМСЫЗ** *с.* 1) Тумышы, чыгышы билгеле булмаган; нәселе булмаган. *Мин ялгыз, токымсыз, нәселсез карчык булып бу дөньядан китәм...* Р.Батулла

2) Чиста токымлы, саф канлы булмаган, катнаш токымлы. *XIX гасыр азакларында Россиядә хәрби ат исәбен алу вакытларында, барлык атларның 60–65 проценты тәбәнәк токымлы, дөресрәге токымсыз буларак теркәлгән, ягъни аларның сыртларына кадәр биеклеге 1 аршын 14 карыштан артмаган.* Безнең мирас

**ТОКЫМЧЫ** *и.* Яңа токым чыгару өстендә эшләүче белгеч, селекционер

**ТОКЫМЧЫЛЫК** *и.* Яңа токымнар чыгару эше, селекция. *Әгәр токымчылык, ягъни селекция эше белән шөгыльләнсәң, бик нык отарга була: бозауларны, бәрәннәрне аерым номерлар сугып, җыеп барырга гына кирәк.* М.Хәйруллина. *Узган ел токымчылык хуҗалыклары да зур эш башкарды.* Р.Баһаутдинов

**ТОКЫН** I *и. диал.* Абзарның аерымланган бер (гадәттә тәрәзәсез) өлеше. *Әүвәлгечә алан-сыртлар буйлап күчереп йөртергә исәбе юк иде аның: малларны Озынталдагы токынга тупларга да мизгел хозурлыгына сокланып ятарга, хыяллар чоңгылына батарга.* Р.Камал

**ТОКЫН** II *с. диал.* Танылмаган, аерылып тормаган, тыйнак. *Безнең башкорт токымы – токын гына бер халык.* Шура

**ТОЛ** I *с.* **1.** Ире яки хатыны үлеп, яңадан өйләнмәгән яки иргә чыкмаган. *Моннан ике ай элек күрше авылдагы ике баланы тол иргә кияүгә чыккан иде.* Л.Ихсанова. *Ханымның тол икәнлеге ачыклануга, Вафа ул якка карамаска --- тырышты. Ханымны кыстамады, бокалын чәкештермәде – барыбер хәләле Шәмсия тол хатыннан көнләште.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Шундый ир-ат яки хатын-кыз. *Ятим калган балалар да, ирсез калган толлар да, бөтен уллары югалткан әбиләр дә бәхетлеләр өчен шатланды.* Р.Батулла. *Әзме авылда алтышар-җидешәр баланы ялгыз үстергән толлар?* Ф.Яруллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Ире яки хатыны үлгәннән соң өйләнмичә яки кияүгә чыкмыйча, җефетсез. *Фәхерниса карчык гомер буена эш яратты, малаем кешедән ким булмасын дип, тол көенчә тырышып карап үстерде.* М.Мәһдиев. *Мине үгилектә калдырмас өчен, әтием бүтән өйләнмичә, тол яшәде, мине үзе кадерләп үстерде.* С.Сабиров

**ТОЛ** II *и. рус сөйл. Нитротолуол* дигән шартлаткыч матдә исеменең кыскартылмасы, тротил. *Поезд якынлашу белән, ул гранатасын нәкъ шул урынга ыргытачак. Тол детонация буенча шартларга һәм күперне күтәрергә тиеш.* Г.Әпсәләмов

**ТОЛ ӘМӘЛ** *и. к.* **тол гамәл**. *Тол әмәлнең башы көлкенеч, ахыры үкенеч.* Мәкаль. *Ансыз Казан тарихында эз калырлык бозык эшләр майтару турындагы хыял тол әмәл генә булып калачак.* З.Мәхмүди

**ТОЛ ГАМӘЛ** *и. бор.* 1) Ире яки хатыны үлгәч яисә нәзер итеп, вакытлыча җенси мөнәсәбәттән тыелып тору йоласы

2) *күч.* Мәгънәсез тырышлык, буш эш

**ТОЛЛАЙ** *рәв. сөйл.* Тол калган хәлендә. *Сәлим хәзрәт[нең] яшь остабикә аласы килә. Чөнки Гаян абыстайны толлай гына алган иде.* З.Һади

**ТОЛЛАТА** *рәв. к.* **толлай**. *Биктимер абзый, егет була торып, Гыйльмиҗамал абыстайны толлата алган.* Г.Толымбай. *Ул пәйгамбәребезгә караганда байтак өлкән, аның өстенә толлата алынган хатын булса да, пәйгамбәребез аны ярата торган булган.* Ислам – татар һәм мөселманнар

**ТОЛЛЫК** *и.* Тол булу, тол булып яшәү хәле. *Җырның беренчесе тәмамланганда, күп кешенең күзендә яшь була, чөнки «герман» сүзе ата-бабадан килгән зур бәхетсезлек, ятимлек, толлыкны аңлата иде.* М.Мәһдиев. *Әкрен генә Бибисара толлык ярасын дәвалады: дөньяда ялгыз хатыннар бихисап, берсе дә тәгәрәп үлми, яши, ул да яшәр.* Н.Гыйматдинова

**ТОЛСТО́ВКА** *и. рус* 1) *иск.* Биле бумалы озынча һәм киң калын ирләр күлмәге. *Ишектән беренче булып Зиннәт абзый, аның артыннан --- кара бәрхет толстовка кигән кеше чыкты.* Г.Галиев. *Бер почмакта билле толстовка, ак киез эшләпә кигән таза бер адәмне ике милиционер тоткан.* М.Мәһдиев

2) *неол.* Эчке кием яки спорт киеме буларак киелә торган озын җиңле, төймәсез трикотаж кофта. *Рәсемле толстовка*

**ТОЛСТОЙЧЫЛЫК** *и. тар.* Рус язучысы Л.Н. Толстойның иҗтимагый стройны патриархаль крестьянлык карашыннан торып тәнкыйтьләү, инкяр итү һәм явызлыкка көч белән каршылык күрсәтмәү, рухыңны камилләштерү идеяләре белән сугарылган дини-әхлакый тәгълиматы. *Эсер Давыт Урманов реакция вакытында әле толстойчылык, әле философ ницшечылык*

*якларына авып чайкала.* Г.Ибраһимов. *Аларның икесендә дә халыкчылык темасы толстойчылык карашлары белән үрелгән.* Р.Ганиева

**ТОЛЫК** *и. иск.* Чи тиредән эшләнгән тоз капчыгы. *Тоз – толыгы белән, кыз – кылыгы белән.* Әйтем

**ТОЛЫКМАН** *и.* 1) Зур бер тоташ төргәк. *Ниһаять, Гали Вәлиевич, толыкманы белән бөкләп, кулына газета тотты.* Ф.Садриев. *Еребезгә дә толыкманы белән акча тоттыручы кеше юк икәнен беләм бит инде мин.* Ф.Баттал

2) Әйбернең кабы-чүбе белән бергә алынган авырлыгы; брутто

**ТОЛЫМ** *и.* Үрелгән чәч. *Рәсемнән, ягымлы гына елмаеп, бер кыз карап тора иде. Үреп салган калын толымнары аны ниндидер сер белән тутыра кебек иде.* Х.Камалов. *Беркайчан тарак йөзе күрмәгән, толымнарга үрелмәгән озын чәчләре, ат ялы сыман таралып, иңбашларына төшеп тора.* Н.Фәттах

**ТОЛЫМБАЗ** *и.* Көнчыгыш халыкларында тәлинкә сыман борынгы бәрмә музыка коралы. *Төрки-татар алынмаларын рус халкының тормышкөнкүрешендә, --- мәдәният һәм фольклор үрнәкләрендә күрергә була. Хәтта музыка кораллары – торба, сорнай, балалайка, барабан, толымбаз (зур барабан) --- – бары да татарныкы.* Ә.Гафуров. *Сугыш вакытында татарлар зур барабан – толымбаз та кулланганнар ---.* Татар, уян!

**ТОЛЫМЛАП** *рәв.* Толым рәвешендә, толым итеп. *Мәйдан уртасына, нәзакәтле атлап, озын зәңгәр күлмәк кигән, чәчләрен толымлап үреп салган кызлар чыгып басты.* А.Вергазов. *Зәйтүнә үзе дә ир хатыны булган кеше, аның әнисе кебек, чәчен толымлап үреп йөрергә тиеш, дип саный.* М.Маликова

**ТОЛЫМЛЫ** *с.* 1) Чәче толымлап үрелгән. *Толымлы кыз*

2) Толымы булган. *Кап-кара ике толымлы, кыйгач кашлы бу кыз бер җәй эчендә үсте дә китте.* М.Мәһдиев. *Кечке уеннарда кызлар арасыннан берсе – озын толымлы, ак кофта белән кара юбка кигән Һәдия исемлесе – күзләрен гел Бакыйдан алмый кебек тоела иде.* М.Маликова

**ТОЛЫП** *и.* Ачык салкын һавада озак булганда, тышкы кием өстеннән киелә торган зур якалы озын, киң мех тун. *Олаучылар өсләрендәге толыпларын, җылы бияләйләрен, туннарын салып бирә: юл ерак, янәсе, без чыныккан кешеләр, ә сез туңып үләрсез.* Р.Мостафин. *Кошёвка сыздыртып үтеп китте, ә кошёвкада, толыпка төренеп, кырын яткан кеше авыл советы рәисе Кара кул Хәбри иде.* Н.Кәримова

**ТОЛЫПЛЫ** *с.* Толып кигән. *Шуңадыр инде авылда бүре толыплы кешеләр (юл йөрүчеләр, тегүчеләр) байтак иде.* М.Мәһдиев. *Толыплы, чикмәнле авыл агайлары чаналарын бер-беренә тәрәбрәк, тартып-этеп куйдылар.* Р.Кәрами

**ТОЛЫПСЫЗ** *рәв.* Толып кимичә, толыптан башка. *Гомеремдә беренче тапкыр чанага толыпсыз утырып кайта Сәлахетдин.* К.Миңлебаев

**ТОЛЬ** *и. фр.* **1.** Су үткәрми торган махсус эремә (битум, сумала) сеңдерелгән катыргыдан гыйбарәт төзү материалы. *Югыйсә түбәне Тимерша үзе яба иде, ә ул --- зур итеп салынган йортка толь тышлы бүрек кидерүне өнәмәде, әнисенең һәм хатынының, хәзергә толь ярап торыр, аннары калайга алыштырырбыз, дигән сүзләренә ачу итепме, тольне үзе үк начарлата иде бугай.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Шул материал ябылган, шул материал белән капланган. *Тимерша түбәне тоташтан тутыя калай белән япты, акчасын кызганмады. Йортлары балкып тора хәзер! Толь түбә төсен бөтенләй дә алып торган икән.* М.Хуҗин

**ТОМ** I *гр. и.* 1) Әсәрләр җыентыгының аерым китап итеп чыгарылган бер өлеше, җилд. *Биш томлык сайланма әсәрләрем чыгып ята. Өч томы – чыкты инде.* Ф.Яруллин. *Әле яңа гына дүрт томлыгым чыкты. Өч томы чәчмә әсәрләрем, яңа хикәяләрем, дүртенче томы киносценарийлар – Тукай, Нуриев, Алып батыр, Аксак Тимер белән болгар кызы Гайшәбикә турында.* Р.Батулла

2) Сериянең, билгеле әдәби хезмәтләр тупланмасының аерым китабы, кенәгә. *Татар әдәбиятын да ике том итеп чыгарганнар. Беренче томга халык авыз иҗаты кергән, икенчесенә – классикларыбыз иҗаты.* Р.Миңнуллин. *Вәлиди хаксызга репрессияләнү сәбәпле, сүзлекнең икенче томы чыкмыйча кала, һәм ул эзсез югала.* Ф.Гаффарова

**ТОМ** II *и. бор.* Мәҗүси дога; имченең чир рухы белән ничек көрәшүен тасвирлап сөйләве. *Име – им, томы том булсын.* Әйтем

**ТОМ** III *кис.* Кайбер сыйфатлар янында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый һәм «бөтенләй, тулы, тулысынча» мәгънәсен белдерә. *Атларны китерделәр: берсе бик зур, бик симез, матур том-кара ат.* Г.Ибраһимов

**ТОМА** *кис. к.* **том** III. *Иҗат куанычын кичерә белгән кеше үзен тома бәхетсез итеп тоя алмый!* М.Маликова. *Гаиләдә берсеннән-берсе яшь дүрт бала тома ятим калды.* А.Хәлим. *Яңа туган көчекләр тома сукыр була.* Р.Батулла

**ТОМÁ БАЛАВЫЗ** *и.* Умарта кортлары әзерли торган җилем. – *Тома балавызның исе бик көчле бит аның... – Тома балавыз? – Әйе, китапча итеп әйтсәк, прополис була инде.* Ф.Яруллин. *Тома балавыз, кайда җыелуына карап, төсләре белән аерылып тора: сары да, коңгырт та, ачык яшел яки кара яшел дә булырга мөмкин.* Шәһри Казан

**ТОМАГА** *и.* Ауга өйрәтелгән ерткыч кошларның күзләрен каплау өчен кидертелә торган күн башлык. *Япанчы --- томагасын ачкан бөркет сыман Карый икән тирә-ягына.* Н.Арсланов. *Бөркетче – тау өстендә, бөркет – аста, Күзәтү ансат болай аулаганда. Томагасын алу белән, ерактан ук, Кыран бөркет үз корбанын сайлаганда, --- Бөркет батыр тырнак җәйгән, калмый таңга.* А.Конанбаев

**ТОМАК** I *и. этн.* Хәзер нигездә казаклар һәм кыргызларның баш киеме. *Икенче сафта карасакаллар – ир уртасы казаклар. Аларның кайсы томактан, кайсы бәрән кырпулы очлы бүректән.* И.Салахов. *Туны өстеннән калын тиредән теккән көбә чикмән, башына ян-яклары җилкәсенә үк салынып төшкән томак – бүрек кигән.* В.Имамов

**ТОМАК** II *и. бор. к.* **тумак**. *Туралы кошның баласы – Томагы күзгә төште лә!* Дастан

**ТОМАЛАН** *и. биол.* Җир астында итләч бүлбесыман үрчү өлеше булган ашарга яраклы сумкалы гөмбә; *русчасы:* **трюфель**. *Томалан кыздыру*

**ТОМАЛАНУ** *ф.* 1) *тош. юн. к.* **томалау**. *Күкрәк-беләкләре дә, нәкъ сакалмыегы кебек, бөдрәләнеп торган кара төк белән томаланган.* М.Хәсәнов. *Табылдык әйбер бөке белән томаланган бер савыт булып чыккан.* Г.Гыйльманов

2) Каплап куелу; бикләнү, ныгытылу. *Тоткыннарга тәгаенләнгән, юанюан тимер рәшәткәләр белән томаланган тәрәзәле боек вагон алдында эре-эре ике төркем кайный ---.* А.Гыйләҗев. *Бер фатирда бүлмә тәрәзәсе биек шифоньер белән томаланган иде, чөнки бабай еш кына тәрәзәдән чыгарга омтыла, дүртенче кат икәнен дә аңламый икән.* Татарстан яшьләре

3) Һава, су һ.б.ш.лар кермәслек итеп төренү, ябылу. *Мәрьям --- яхшылабрак, томаланыбрак киенде.* Н.Фәттах

4) Һавасыз, сулышсыз һ.б.сыз калу, изоляцияләнү. *Орлыкларым вакытында чыга алмый калганнар, кайберләре, томаланып, бөтенләй черегәннәр.* Г.Ибраһимов

5) Җан иярләрендәге күз, колак кебек әгъзалар томан, яры, элпә һ.б.ш. белән капланып, сиземен югалта төшү, тоныклану, томанлану. *Башыма кан бәреп, колагым томаланды, бүлмәдәге ыгызыгыны томан аша күргәндәй карап торам.* Л.Ихсанова. *Кичә берәү аның янына гозер белән килгән иде. – Әниемнең күзләре томаланды, врачлар да ярдәм итә алмый, – диде ул кеше.* М.Маликова

6) *куч.* Дөнья хәлләреннән хәбәрсез булу. *Үз ирегеңдә йөрү нинди рәхәт, иеме, абый! --- Кичләрен өйдә томаланып ятулардан тәмам гарык булган идем.* Э.Касыймов. *--- шушы ике кеше турында уйлау Михаилга чиксез ләззәт бирә, хәтта чиркәү стеналары арасында томаланып яшәгәндә дә --- ул аларны күз алдына китерүдән тыела алмый иде.* М.Кәбиров

7) *куч.* Һуштан язу, аңсызлану; зиһенсезләнү. *Әнвәр, кайтып, ылыс идәнгә ауды. Аяк табаннары сулыксулык килеп авырта, буыннары гүли, башы, зиһене томаланган.* Х.Камалов. *Аяусыз хөкем чыгарды хатын, ләгънәт укыды, каргады. Бер уйласаң, ул хаклы түгелмени? --- Ярый әле чирләмәде, хисләргә тулышып, мие томаланып, җирдә тәгәрәмәде.* А.Гыйләҗев

**Томалана башлау** Томалану билгеләре сизелү. *Батыргали агай, бик исерек булмаса да, яхшы ук кызган, күз аллары томалана башлаган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Рухы төшеп, уйга чумган Фәргиз туңып томалана башлаган тәрәзәдән тышка карап торганда, эреле-ваклы этләр ияртеп, Дамка кайтып керде.* З.Фәйзи

**Томалана төшү** Беркадәр томалану; тагын да ныграк томалану. *Башта, салкын суктымы икән әллә дип, күршесеннән күзләренең бәбәгенә корт балы салдырып карады, файдасы тимәде, фельдшердан күз даруы алдырды, томалана төшкән кебек кенә булды күзләре.* Сөембикә

**Томаланып алу** Бераз томалану. *Ул хәтәр дәвердә кешеләргә золым-золмәт мөһере итеп сугылган 50 нче статьяның шомлы пунктлары, кешене --- танышларына яла ягарга мәҗбүр итәр өчен кулланылган җәзалау алымнары хакында укыганда гына да зиһене томаланып алгандай була.* Ф.Дунай. *Тик ун еллап инде күзләре күрми, вакытывакыты белән колагы томаланып ала, шуңа кычкырыбрак сөйләшергә туры килә.* Туган як

**Томаланып бару** Акрынлап томалану; торган саен ныграк томалану. *Аның үзенең дә бер күзе томаланып бара иде.* Ә.Хәсәнов. *Ләкин күңеле, сабыр ит, көт, чит кеше түгел бит ул сиңа, сөйләш, кайбер нәрсәләргә миең дә томаланып бара торгандыр, дияр иде.* Х.Хәйруллин

**Томаланып бетү** Тәмам, тулысынча томалану. *Әллә нинди спектакль иде ул. Туктаусыз атыш: шарт та шорт. Колаклар томаланып бетте.* Э.Касыймов. *– Китап укыйукый томаланып беткәннәр! – дип, Хәмиткә бүлмәдәшләреннән зарланды.* Ф.Яхин

**Томаланып җитү** Тулысынча томалану; тиешле дәрәҗәдә томалану. *Томаланып җитмәгән кибәннәрнең үзәгенә су үтә.* А.Шамов

**Томаланып калу** Нindидер сәбәп аркасында томалану. *Тиздән Газиз исемле малай белән бәйле өметләре үлем, теге дөнья хакындагы шомлы уйлары астында басылып, томаланып калды.* Г.Гыйльманов

**Томаланып килү** Акрынлап томалану, томалана башлау. *Администраторлыкны төп эш стиле дип санаган һәм үз фикереннән чыгып кына командалык итәргә яраткан элекке председатель заманында томаланып килгән уй-фикерләр бөтенесе дә өскә калкып чыктылар.* Г.Шәйхи. *Һәр авыл башында ук чүп-чар оясы, томаланып килгән чишмәләр, эшләмичә сусыз утыручы колонкалар, җимерек күперләр...* Татарстан яшьләре

**Томаланып киту** Кинәт кенә томалану. *Күз аллары томаланып китте, колак төбендә әлеге приказчикның: «Җае чыкканда файдалана белмәсәң, беркайчан да кеше була алмассың», – дигән сүзе яңгырап торды.* М.Галәү. *Ләкин картның канәгать кыяфәтен күргәч, кинәт мие томаланып китте.* М.Маликова

**Томаланып кую** Алдан ук томалану; кинәт кенә томалану. *Буа тавышы бер акрыная, бер көчәя. Бәлки, Бибинурга гына шулай ишетеләдер ул, чөнки аның зиһене кайчагында томаланып куя, колаклары ишетмәс хәлгә килә.* А.Гыйләҗев. *Аракыдан мие томаланып куйган Мотаһар аяк астындагы нәрсәләргә абына-сөртенә килеп, ишеккә капланды ---.* А.Хәлим

**Томаланып тору** Даими томаланган хәлдә булу; вакытлыча томалану. *Аның бөтен тәне авыраеп, башы томаланып тора, һәм кул-аяклары хәлсез яналар.* Ә.Еники. *Бу уйлары патша заманнарында ук барлыкка килеп, илгә совет кергәч онытылып һәм коммунистик кызыл таш белән бастырылып, томаланып торды.* Ф.Яхин

**ТОМАЛА́У** *ф.* 1) Нинди дә булса өслеккә икенче бер әйбер түшәү, җәю, тишек-ярыкны берәр нәрсә белән каплау. *Кар астына су төшкәч, сукмакка*

*«алдавыч» ясыйсың: көрәк белән карын алып, чокырына су тулгач, өстән юка гына кар белән томалыйсың.* Ш.Галиев. *Куян эзләре дә күңелне күтәрә. Алар шушы тирәдә генә бәрәңге базларының өстен томалаган салам өемнәре янында уйнаклап йөргәннәр бит.* А.Гыйләҗев

2) Берәр әйбернең өстен капкач яки башка берәр нәрсә белән каплап кую, ябып кую. *Нәҗип мунча мичен томалап, салкын-кайнар суларны әвештәвеш китереп көйләп чыккач, күңеле борлыгып, инеш буйларын тагын бер урады.* А.Гыйләҗев. *Әнисе, самавырын томалап, сөйләнә-сөйләнә, ишегалдына чыгып китте.* Р.Вәлиев

3) Тән, баш, кул-аяклар һ.б.ш.ны нәрсә белән дә булса ябу, бөркәү, каплау. *Әнкәсе, кече якка ашыга-ашыга урын җәеп, балаларны тиз-тиз йокларга салды, өсләреннән кат-кат юрган белән томалады ---.* Г.Галиева

4) Билгеле бер урынны, җирлекне тоташ каплау, берәр нәрсә белән ябу. *Бала куркып җыларга тотынды, ләкин ана кеше шундук аның авызын шәл очы белән томалады ---.* Н.Фәттах. *Өченчесе эчендәге пуля ярасын кулы белән томалап тоткан.* Р.Сәгъди

5) Күрү, күренү мөмкинлеген чикләү, ышыклау, өртү (болыт, томан, караңгылык, күз яше һ.б.ш.лар тур.). *Кала өстен томалап, тузан баганалары күтәрелде.* М.Хәсәнов. *Көн бик сәленке иде, күк йөзен кара болыт томалаган --- иде.* М.Хәбибуллин. *Бу сүзләрдән соң читтәрәк утырган Шәргыянең күзләрен яшь томалады.* Г.Галиева

6) Берәр өслеккә тоташ яту, тулысынча ябу, каплау, күмеп китү. *Ләкин кар ябалак-ябалак булып ява бирде, җир өстен томалады.* Р.Ишморатова. *Матур булып үсеп килгән бәрәңгеләр, инде тирес өстен томаларлык булган кыяр, гөрләп-яшьнәп утырган яшелчә түтәлләре – берсе дә Гөлбеттин бабайны куандыра алмады.* Р.Гариф

7) Тәрәзә, ишек һ.б.ларны берәр нәрсә белән ябу, каплау. *Өйалдында чыбылдык белән томаланган бер карават тора иде ---.* М.Мәһдиев. *--- авылның иң читендәге, тәрәзәләре такталар белән томаланып, каралты эчләренә, якын-тирәләренә әремнәр үсеп беткән өйдә яшь бер ир-егет кеше күренгәли башлады.* Р.Гариф

8) Тоташ буяу; сөртү. *--- гель яки лак белән томаланган дәүләт номерын юл-патруль хезмәтендә эшләүчеләр дә, видеокамералар да бик яхшы таный.* Ватаным Татарстан

9) Үз гәүдәң белән каплау. *Бөек Ватан сугышы чорында --- Александр Матросовтан бер ел чамасы алдарак, 1942 елның 31 мартында, күкрәге белән дошман амбразурасын томалап, сугышчан иптәшләренә җиңү өчен юл ачкан гвардияче каһарман ул!..* Ш.Мостафин

10) Берәр нәрсә икенчесен күренмәслек итеп ышыклап тору. *Ачуым килсә, җәй белән кышны үземнеке итәм, зәһәрем чыкса, күләгәм белән кояшны томалыйм.* Т.Миңнуллин

11) *күч.* Күңелне, эчке дөньяны биләп алу (кайгы-хәсрәт, борчу, сагыш, күңелсезлек һ.б.). *Моңарчы Мирвәли, нинди дә булса кирәксез уй миеңне томалый икән, андый чакта шул уйны бик ныгытып, тоташтан уйларга кирәк, шунсыз аннан котылу әмәле юк, дип инанып яши иде...* А.Гыйләҗев. *Бу, әлбәттә, куркак җаннарның наданлыгын көчәйтә, күзләрен сукырайта, күңелләрен томалый иде.* Ф.Яхин

12) *күч.* Кимчелекләрне, начар эшләрне яшерү, яшереп калдыру, күрсәтмәү. *Кайбер язучылар авыл тормышыннан алып язылган драма әсәрләрендә кыз белән егет арасындагы мәхәббәтне төп тема итеп алалар да шул чорның политик, экономик шартларын томалап калдыралар...* К.Гыйззәтов. *Халык телендәге сүзләргә караганда, алар, эчке хискә бирелеп, күп урында, татарларга ачудан фанатик берьяклылык белән, дөреслекне томалап калдырганнар.* Шәһри Казан

**Томалап алу** Кинәт, һәрьяклап томалау; тиз генә томалау; вакытлыча томалау. *Ишек янын таза ирләр томалап ала.* М.Мәһдиев. *Бөтен өй эчен ниндидер куе караңгылык томалап алгандай булды, күз алдындагы әйберләр күренмәс, тавышлар ишетелмәс булды.* Н.Фәттах

**Томалап бетерү** Бөтенләй томалау; барысын да томалау. *Черки күплектән битен-күзен яулык белән томалап бетергән Фәридә, күрәсең, әле яңа гына басудан кайтып, --- табак-савытларны юып ята иде.* Н.Фәттах. *--- яшен яшьни дип, бөтен утларны сүндереп куйды, --- көзгеләрне томалап бетерде.* А.Әхмәтгалиева

**Томалап карау** Томаларга тырышу; сынау өчен томалау. *Сул кулы белән тез башын томалап карады, итәкне тартып төшерергә тырышты, барыбер тезләр ачылып калды.* А.Гыйләҗев. *Алай да итеп карадылар, болай да, колакларын мендәр белән дә томалап карадылар – барып чыкмады.* Р.Мөхәммәдиев

**Томалап китү** Тулысынча томалау. *Юлларны, авыл урамнарын көрт басты, елгаларны ярлары белән тигезләде, ул гына да түгел, таң атканчы, кайсыбер өй ишекләрен томалап китте.* Д.Бүләков

**Томалап кую** Томаланган хәлгә китерү. *Кышын тәрәзәләрен кар томалап куя икән.* М.Маликова. *Аның күзен томалап куя алмыйм ич инде мин.* Ә.Хәсәнов

**Томалап тору** Томаланган хәлдә тоту; билгеле вакытка томалау. *Алексей җиргә тезләнә, башын ике учы белән кыса, колакларын томалап тора, тик алай да чыдый алмый.* Х.Камалов. *Төштән соң башланган пыскак яңгыр һаман сибәли, куе томан кебек, әйләнәтирәне томалап тора.* С.Сабиров

**Томалап чыгу** Барысын да томалау. *Кортларның утырып беткәннәрен көтеп, оя авызларын юеш чүпрәкләр белән томалап чыкканчы, төнге унберләр дә җиткәндер.* А.Хәсәнов

**Томалый башлау** Томаларга тотыну. *Ахырында шәһәрне караңгылык томалый башлады.* С.Җәлал. *Бервакыт алтын-көмеш өеме байның муенына җиткән, авыз-борынын каплаган, күзләрен томалый башлаган...* Г.Гыйльманов

**Томалый төшү** Бераз томалау; тагын да күбрәк томалау. *Аты алдына йомшак солы саламы салды да, алачыкның бөркәвен чак кына томалый*

*төшеп, өйгә керергә булды.* М.Хәсәнов. *Гөлфирә пәрдәне томалый төште, ләкин, сызык кына ачык калдырып, күзәтүен дәвам итте.* Г.Кашапов

**ТОМАН** *и.* 1) Атмосферадагы эссе һәм салкын һаваның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән су пары кисәкчекләре массасы. --- *бүген тау итәкләрендә көне буе томан йөзә, олы тау үзе бөтенләй күренми үк, түбәсенә хәтле күксел болыт сарган.* К.Миңлебаев. *Тәкәшүр болынының Чулман ягында, бик зур болыт сыман булып, аксыл томан күтәрелде.* Н.Фәттах

2) Һаваның үтәкүренүчәнлеген киметә яки җуя торган һәртөрле масса (рәшә, тузан, төтен һ.б.). *Әйтерсең лә җәйге кайнар рәшә Югарыга сине, күккә дәшә. Тынычланып калган сыман булып, Ул тарала җиргә томан булып.* Җ.Дәрзаман // Бу, пар. *Бусага аша үткәч, іяреп кергән суык томаны аша хатыны Бибигайшәнең тантаналы итеп боерган тавышын ишетте ---.* З.Зәйнуллин

3) *күч.* Күрергә, сиземләүгә яки фикерләүгә комачаулык итә торган халәт. *Шуннан аңымны ниндидер томан каплап китте, ди, әй рәхәт үзе, тоташ мамык эчендәмен имеш, ә йокы бал күк татлы, бөтен тәнне камырга әйләндергән, ди.* Х.Камалов. *Көн аяз, табын күрекле, хезмәттәшләр ачык йөзле иде, әмма, нилектәндер, Мәрьямнең башын сарган томан таралмады.* М.Маликова

4) *күч.* Ачык, анык, төгәл булмаган нәрсә. *Күрәсең, аңа [Нәфисәгә] бик ачык булган нәрсәләр дә кайберәүләр өчен куе томан икән әле.* Г.Бәширов. *Сөйгәнем белән кавышу шатлык кына түгел, үкенеч газабы да китерде. Киләчәгем билгесез, томан эчендә иде.* Р.Габделхакова

**ТОМАНА** *с.* **1.** Әйләнә-тирә хакында белеме чикле, надан, аңсыз. *Ася үзе дә томаналардан түгел, китап укырга ярата. Күбрәк чит ил авторларын.* Х.Камалов. *Мәктәптә укытучы бер томана балага икеле утырта.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *– Без монда берни белми ятабыз, томаналар, – диде Фәрхәнә апа, үз-үзен тәнкыйтьләп.* Н.Фәттах. *Аннары сакчы, аркасына мылтык терәп, картны Миңнулла бүлмәсенә алып керде дә: – Уф, нишләтим икән, иптәш Гайсин, бу томананы? – диде.* В.Нуруллин

**ТОМАНАЛАНДЫРУ** *ф.* Томанага әйләндерү, зиһенен томалау, аңсыз итү. *Егет чагында «артык чибәр хатынга ышанырга ярамый, Әлфияне кыз чагында ук ирләр белән күргәләгәннәр» дигәннәр иде, игътибар итмәде, мәхәббәт кешене томаналандыра икән.* Т.Галиуллин

**ТОМАНАЛЫК** *и.* Томана булу, аңсызлык, наданлык. *Әзимов янында томана булуың бик ачык күренә. Әнвәр, үзенең томаналыгын белгертмәс өчен, сүзгә кушылмый, бары гаепле елмаеп, ияк каккан булып утыра.* Х.Камалов. *Юләр сөальнең хатын-кызны рәнҗетә, кимсетә торган ахмаклык, томаналык икәнлеген аңлады Сәет.* Т.Галиуллин

**ТОМАНЛАНДЫРУ** *ф.* Томан белән каплау, томанлы итү. *Баса йолкуы бик авыр. Исе башны миңгерәүләндерә. Берәр сәгать йолкыйсың, күз алларын томанландыра ---.* Х.Камалов

**ТОМАНЛАНУ** *ф.* 1) Һавада томан хасил булу. *Әнә бер сүзе дә чыкмаган шофёры салкыннан томанланган, бер генә җан иясе дә күренмәгән тып-тын урамда --- басып калды.* Ф.Баттал

2) Ачык булмау; томан, төтен, рәшә һ.б. аркылы тонык күренү. *Кызыл парга охшап, томанланып Кояш карый кырга.* Ш.Маннур. --- *тузан белән җилдән тирә-юнем томанланды, кояш нурларының шәүләсе күзләремне чагылдырып үтте.* Т.Кәримов

3) Томанлыга әверелү, томанлы булып тору. *Елан, авызыннан угын чыгарып, күзләре алдында һава томанланып, бөтен каны кайнап каһәрләнә башлады.* Г.Тукай

4) *күч.* Тоныклану, күрмәс булу. *Нәүмиз Фәгыйлә причалда ялгыз торып кала, күзләре томанлана.* С.Сабиров. *Шурик аракыдан томанланган карашын тәрәзәгә төбәде ---.* Х.Ширмән

5) *күч.* Ачык итеп аңлау, фикер йөртү, сиземләү һ.б.ш. сәләтләр чикләнү. *Кайдадыр кечкенә генә өмет чаткысы чагылды. Томанланган зиһене ачыла төште.* Г.Әпсәләмов. *Ачудан аңым томанланган: мылтыкны онытып калдырганмын.* З.Хәким

6) *күч.* Мәсьәлә катлаулану, чуалу, ачык, анык, билгеле булмау. *Шулай итеп, «бару-бармау» мәсьәләсе, Әминә белән сөйләшкәннән соң, бигрәк тә буталды, бигрәк томанланды* ---. Ф.Әмирхан

**Томанлана бару** Торган саен ныграк томанлану. *Казаннан ераклашып, туган авылына таба якыная барган саен, Зәлиянең күз алдындагы сурәте томанлана бара, ә бабасының сурәте ачыклана.* Р.Вәлиев. *– Менә бу Зуля була, Данис абый. – Ә-ә! – Данисның томанлана барган күз карашы ачыла төште.* Р.Галиуллин

**Томанлана башлау** Томанлану билгеләре күренү. *Меңбашы, хәйләкәр елмаеп, томанлана башлаган күзләре белән аңа карап алды.* Р.Сәгъди. *– Кызык, бик тә кызык, – дип, Динар әңгәмәдәше сөйләгән хәлләрне сыра белән томанлана башлаган башыннан үткәрде.* Х.Әпделмәнов

**Томанлана төшү** Бераз томанлану; тагын да томанлырак хәлгә килү. *Эчми эчкән Зөфәргә җитә калды: тамырлары буйлап рәхәт җылы таралды, йөзе аз гына алсуланып кызарды, күзләре чак кына томанлана төште ---.* Ә.Еники

**Томанлана язу** Чак кына томанланмый калу. *Кызының үлемен томанлана язган аңы аша үткәрүче Ана, соңгы ихтыяр көчен җыеп, каршында басып торган доктор алдына тезләнде ---.* Яшел Үзән

**Томанланып бетү** Тәмам, бөтенләй томанлану

**Томанланып калу** Ниндидер сәбәп аркасында томанлану. *Яшь җегет калтыранып китте, иңбашлары салынып төште, күз карашы томанланып калды.* Н.Фәттах

**Томанланып китү** Көтмәгәндә томанлану. *Әмма бераздан аның кайчандыр чем кара булган, хәзер инде үз төсләрен җуя башлаган күзләре җылымса көндәге тәрәзә пыяласыдай томанланып киттеләр.* Г.Әпсәләмов

**Томанланып тору** Томанланган хәлдә булу. *Монда ул --- бөтенләй икен-*

*че төрле зәңгәрләнеп, томанланып торган серле офык һәм төпсез күк йөзен күрде.* Н.Фәттах. --- *томанланып торган көн кинәт кенә ачылып китте ---.* Ф.Садриев. *Касыймның карашы томанланып тора, ни уйлый: хуплыймы ул энесен, әллә гаеплиме – һич аңларлык түгел иде.* М.Маликова

**ТОМАНЛА́У** *ф.* 1) *з.-сыз* Томан төшү, томанлы булу. *Җил салкынайтып тынса, томанлар.* Сынамыш

2) *күч.* Фикер йөртү, сиземләү сәләтен юкка чыгару; мине томалау. *Көн шаукымы Нурһадиның башын томанлады, уйларын икенче эзгә борды.* Ә.Моталлапов

3) *күч.* Күрмәс итү, тоныкландыру; томалау. *Нинди газап күзләреңне томанлады, Нинди кайгы болай сине басты, дисен.* З.Хәким

**ТОМАНЛЫ** *с.* **1.** 1) Томан төшкән. *Минә шул чакта, томанлы, җылы, язгы көннәрнең берсендә, карт Идел үзенең кышкы авыр йокысыннан уяна.* Г.Әпсәләмов. --- *әллә ниткән томанлы тарлавыклар, ак болытлы тау аралыклары, ак каз мамыгыннан ясалган кибәннәр мине, тирбәтә-тирбәтә, әллә кая алып баралар иде ---.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Ачык булмаган, тонык; билгесез. *Шулай да бу чәкләшү, егетнең беленер-беленмәс томанлы тойгыларына ачыклык биргәндәй, очкын элдереп җибәргәндәй итте.* Х.Камалов. *Элек күл булган шактый киң чокыр шәйләнә башлагач, ул шул тарафта ниндидер томанлы шәүлә абайлаган иде, бара-бара, шәүлә кеше кыяфәтенә керде.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Ачык итеп түгел. *Буранлы төндә Гайния кочагына чумуын Мисбах томанлы гына хәтерли.* Н.Әхмәдиев. *Гадәттәгечә, Шубарин томанлы сөйләшә, сүзләрен серле һәм усал итеп әйтә белә, моңа Әкрәмхуҗаев ияләнгән иде инде.* Р.Мирхәйдәров

**ТОМАНЛЫК** *и. астр.* Галәмдәге җисемнәрнең томан рәвешендә күренгән төркемнәре. *Күктә Киек Каз Юлына иң якын торган икенче бер галактика – Андромеда томанлыгы бар.* А.Тимергалин. *Айчибәр ятлар кочагында, ә мәхәббәт йолдызлар аръягындагы томанлыкка болыт булып таралган.* Н.Әхмәдиев

**ТОМАНСУ** *с.* Бераз томанлы, сыек томан белән капланган яки өртелгән. *Акрын гына кузгалып киткән зур пароходны Фәгыйлә, күзләре белән озатып, ерактагы томансу пәрдә эчендә эреп югалганчы, онытылып карап торды.* С.Сабиров. *Күктәге томансу һаваны ертып, сабын заводы ягыннан төтен баганалары күтәрелә.* Р.Низамиев

**ТОМАНСУЛАНУ** *ф.* Томансу һава аша тоныграк булып күренү; томанлы булып китү. *Киң басулар, сузылып яткан таулар, томансуланып, урман күренә безнең тәрәзәләрдән.* М.Хуҗин. *Кара, нинди еракларга бормаланып-сырмаланып китә икән бу таулар, сыртлар, үзәннәр! Ерагайган саен, төсләре томансулана, --- күз аермас төтенсел карасу төскә кереп, ерак офыкларга барып тоташа алар...* М.Рәфыйков

**Томансуланып тору** Томансуланган хәлдә булу; әле, хәзер томансулану. *Иртән урман-кыр өсләре томансуланып тора*

**ТОМАР** *и. иск.* 1) Бөти салынган өчпочмаклы күн янчык, муенга, иңгә һ.б.га асып йөртелә торган баулы бөтилек. *Буй томары. Муен томары*

2) *тар.* Васыятьнамә, ярлык һ.б. төреп салынган җиз көпшә (түрәнең, туй башының һ.б.ның дәрәҗәсен белдергән таяк (жезл) сыйфатында да кулланылган). *Түрә томарын нык тоту*

**ТОМАТ** *и. исп.* 1) Помидор. *Күтәрелә төшкән саен, томат сабакларын таякларга бәйли торды.* Ә.Хәсәнов. *Чәчәкләр белән бергә яшелчә: кыяр, төрле сорт томат, суган, кишер, бәрәңге, чөгендер, салатлар үстерәбез.* К.Хөрамшина

2) Помидордан ясалган пюре, соус. *Пешкән яфракларны өсте ябулы аерым кастрюльдә май, суган, томат салып парландырыгыз.* Г.Мөхәммәтшин. *Балык тоталар, помидор үстереп, томат ясыйлар.* Г.Нурулла

**ТОМА́У** *и.* Борын куышлыгының лайлалы ярысы ялкынсыну (бүлендек, төчкерүләр белән характерлана). *Температурам, әкренләп, утыз җидегә кадәр төште, баш авыртуы һәм томау да бетте диярлек, тик ютәл генә һаман җибәрми иде әле.* Ә.Еники. *Борынына томау төшкәнме, тамагы бераз карлыкканмы, Клара бюллетеньдә иде, ул көнне эшкә чыкмады.* А.Хәсәнов

**ТОМАУЛА́У** *ф.* Томау белән авыру. *Томаулаган сарыктай төчкеренеп тик утыра.* Ф.Яруллин. *Ул иркә сүзләр, назлы карашлар, томауласам да борчылып йөрү синнән генә эләкте миңа, Фидан.* Э.Яһүдин

**Томаулап алу** Кыска гына вакыт эчендә томаулау. – *Ә грипп белән авырмаган идегезме? – Шул грипп булды микән, томаулап алган идем алуын.* Х.Сарьян

**Томаулап йөрү** Әле, хәзерге вакытта томаулау, томаулаган хәлдә булу

**Томаулап кую** Тиз арада, кинәт кенә томаулау. *Озак йөрмәгез урамда Декабрь кичләрендә. Юкса куярсыз томаулап, Суыкта күп йөрсәгез.* Ф.Мәҗитов

**Томаулап тору** Әле, хәзер бераз томаулау

**Томаулый башлау** Томауларга тотыну, томау билгеләре күренү. *Томаулый башладыңмы, көт тә тор грипп киләсен, шуңа күрә тизрәк дару кап, әни.* Яңарыш

**ТОМАУЛЫ** *с.* Томау белән авырган, томау төшкән. *Һәм томаулы килеш киттем шулай Кыз чакырган махсус урынга.* М.Җәлил. *Сөмбелә --- үзенең күз яшьләрен сеңдергән зәңгәр бизәкле кульяулыгы белән егетнең томаулы борынын сөртте.* К.Кәримов

**ТОМЛЫК** *и.* **1.** Билгеле сандагы китапларга бүлеп тупланган басма әсәрләр җыентыгы. *Монда Ленинның утыз томлыгы, Маркс, Энгельс әсәрләре, дәреслекләр һәм әдәби китаплар: Горацийдан башлап М.Горькийга хәтле.* И.Салахов. *Бу арада Галимҗан Ибраһимовның өч томлыгын кулга төшердем.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* Билгеле сандагы томнарга бүлеп урнаштырылган. *Татарстан китап нәшрияты күптән түгел республиканың халык шагыйре Роберт Миңнуллинның җиде томлык әсәрләр тупламын бастырып чыгарды.* Н.Хисамов. *Казакъ теленең ике томлык сүзлеге басылып чыккач, галимнәр*

*унике томлык сүзлек төзүгә керешteләр.* Ф.Хәкимҗанов

**ТОМНА́РЧА** *с.* Томнар белән исәпләнгән, том-том. --- *Кеннет Краггның «Заман мөселманына кагылышлы дәресләр» исемендә бастырган әсәрләре гарәп галәмендә һәм Көнбатышта байтак галимнәрне томнарча әсәр язарга этәр[де]* ---. З.Вәлиди

**ТОМО́ГРАФ** *и. гр. мед.* Объект катламнарының күләмле сурәтен бирә торган аппарат. *Әлеге вакытта монда төп медицина җиһазлары – циклотрон, позитрон-эмиссион томограф, радиохирургия өчен «киберпычак» аппараты урнаштырылган.* Р.Вәлиева. *Күптән түгел генә бирeдә уникаль технологияләргә ия томографлары булган МРТ кабинеты ачылды дип беләм.* Шәһри Казан

**ТОМОГРА́ФИЯ** *и. гр. мед.* Кеше әгъзаларын томограф ярдәмендә тикшерү. *– Маһирә Хәбировна, – дип, профессор дәвалаучы врачка борылды, – үпкәләрнең томографиясен --- әзерләргә кушыгыз.* Г.Әпсәләмов. *Шәфкать туташы чираттагы табиб кабинетына озатып куйгач та, я рентген, я томография, я УЗИ ясыйлардыр дип, халатымны салырга җыендым.* Х.Ширмән // Шундый тикшерү нәтиҗәсенең басма формасы

**ТОМРАЕП** *рәв. к.* **томырылып**. *Шул хәлне күргән Ильяс китапны артка яшергәндәй итте дә Рәгыйдәгә текәлде. Рәгыйдә шулай ук аптырап, томраеп карады.* Ә.Баян

◊ **Томраеп торган** *к.* **томырылып торган**. *Икесенең дә зур томраеп торган күзләре, кара бөдрә чәчләре, алсу битләре --- аларны күз өстендә каш итеп күрсәтә иде.* Ф.Яхин. *Түп-түгәрәк йөздә этиемнекедәй томраеп торган күзләр.* А.Әхмәтгалиева

**ТОМРАП** *рәв. диал.* 1) Тулы булып, тулылык белән. *Идел тынып, томрап ага.* Г.Әпсәләмов

2) *к.* **томырылып**. *Сискәнеп күзләрен ачты һәм диварда эленеп торган кыз рәсемен күрде. Җан иңгән диярсең, томрап карап тора.* М.Маликова

3) Бар көчкә, зур тизлек белән. *Шуннан соң [атлы] егетләр, томрап чабып, Михельсон гаскәренә барып кергәннәр.* К.Насыйри

◊ **Томрап торган** 1) Сау-сәламәт; тазалык, бөтенлек һәм яшәү дәрте ташып торган, тере, елгыр. *Үзе кебек үк зур күзле, олырак авызлы томрап торган улы дөньяга килгәндә, Әхтәри Берлин янында бәләкәй генә зиратта --- ята иде инде.* А.Гыйләҗев. *Безнең картаймыш көнебездә томрап торган оныклар сөясебез, --- иркәлисебез килә, дигәннәр.* Ф.Яруллин; 2) *к.* **томырылып торган**. *Шуның томрап торган күзләре, энҗедәй тезелеп киткән тешләре, дулкын-дулкын чәчләре төшләремә кереп саташтыра, ди, балакаем.* Ф.Яруллин

**ТОМРАЮ** *ф.* 1) *к.* **томсаю**

2) Болытланып китү, болытлау. *Күк йөзе томраеп тору*

**ТОМРЫЙ** *с. диал.* Ялтырап торган үтә, чем (төс тур.). *Күзе дә томрый кара, чәче дә томрый кара.* Җыр

**ТОМСА** *с.* 1) Тонык, томанлы. *Кояшсыз томса таң туды, ә эти кеше кайтмады.* Г.Якупова

2) *күч.* Караңгы чырайлы, тупас, ягымсыз. *Әбисен, элеккеге тормышын сагыну катыш бар кичерешләре күңелен тупасландырдылар, үзен усал, аз сүзле, томса бер кыз балага әверелдерделәр.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ТОМСАЛАНУ** *ф.* Томса (*1 мәгъ.*) булып китү. *Яшел пальтоң белән җилтерәп килеп кердеңме, бүлмәнең төсе китә, көзгеләр томсалана, билләһи.* Ә.Фәйзи

**Томсаланып тору** Томсаланган хәлдә булу; әле, хәзер томсалану. *Көзге көн томсаланып тора*

**ТОМСАРУ** *ф.* 1) Томса булып китү. *Карашы томсару*

2) *к.* **томсаю**. *Бүлек мөдире томсарып карап торса да, үз фикеребездән кайтмадык*

**ТОМСАЮ** *ф.* Томса, кырыс булып китү, кырыслану. *Рияланып кына, сер алыр өчен генә елмайган була бандитлар. Менә күрерсең, кырга чыгып киткәч томсаерлар.* Л.Гомәров

**ТОМСЫК** *с. диал.* 1) Караңгы, төксе. *Томсык чырайлы кешеләр кәефне төшерәләр*

2) Сүзсез, бик аз сүзле. *Сүз тыңлаучан, томсык малай булып үстем.* Казан утлары

3) Эчкә батып торган, билле, яньчек. *Мин томсык борынлы, ямьсез генә бер кыз. Мин гомерем буе шушы яньчек борыным өчен хафаландым.* Р.Батулла

**ТОМСЫ́К ГӨМБӘ** *и. бот.* Чебен гөмбәчәләре семьялыгыннан аксыл яшькелт эшләпәле, ак саплы, яфраклы урманнарда үсә торган гаять агулы гөмбә; *русчасы*: **поганка бледная**. *Агулы гөмбәләр арасында иң куркынычы – томсык гөмбә, ул үлемгә дә китерергә мөмкин.* Биология

**ТО́М-ТОМ** *с.* Күп томнардан торган, күп томнар рәвешендәге. *Аның йорты юк, гаиләсе юк, якын туганнары юк, аның нәселе калмый, ләкин аның том-том китаплары кала* ---. Р.Батулла. *Аның әлегә кадәр басылган һәм киләчәктә басылачак том-том хезмәтләрен өйрәнү өчен, махсус бер академия кирәк булачак.* М.Галиев

**ТОМШЫК** *и.* 1) Кош авызының мөгез катлаудан гыйбарәт, алга таба очлаеп чыгып торган, эләктереп алу, чуку әгъзасы, борыны. *Кайдадыр тукран агач кайрысына томшыгы белән бәрә.* Г.Әпсәләмов. *Әлфиянең Кенәри исемле бик матур кошы бар. Каурыйлары да сары аның, томшыгы да сары, хәтта шырпыдай неп-нечкә тәпиләре дә кызгылт сары.* Г.Сабитов

2) Ташбака, үрдәкборын, башаяклы моллюсклар һәм кайбер динозаврларның мөгез катлаудан торган озынча тешсез казналыгы

◊ **Томшык борын** Очы аскарак бөгелеп, бөкрәеп торган борын, карчыга борын. *Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Поцелуйкин, кулларын угалап, утырган урынында сикереп куйды, мәченеке кебек яшел күзләре кечерәеп, җыерчыклар эчендә тәмам югалып калды, томшык борыны тагын да нечкәреп киткәндәй булды.* Г.Әпсәләмов

**ТОМЫЛУ** *ф.* Зур омтылыш белән һәм бар көчкә тырышып йөгерү, чабу. *Ул сүзсез калды, беравыктан, томылып, өйләренә йөгерде.* А.Гыйләҗев. *Менә әнкә песи --- баласының колак артларын «тешләп» алган була, аннары*

*читкәрәк китеп, сабыена ерактан сокланып --- ала. Ә сабые, тәкатьсез калып, томылып килә дә әнкәсенең җылы куенына башын төртә.* М.Галиев

**ТОМЫРУ** *ф.* 1) Кинәт кенә алып бәрү, ату, көч белән атып бәрү, селтәнеп ыргыту. *– Юк, руслар бирелми! – дип кычкырды да трубалы фашистка граната томырды.* Г.Әпсәләмов. *Сәкинәне «табигать авазы», инстинкт харап итүен аңлаган Сәхия үзенең хатын-кыз киемнәрен утка томыра.* Ф.Яруллин

2) Күтәреп бәреп яру. *Ярсаң ике, томырсаң өч булырлык гәүдәсе белән, кыз баланың ял белмичә көнен-төнен эшләп алган акчасын --- әрәм-шәрәм иткән җилкуар да өлешсез калмады.* М.Хәсәнов

3) Бик каты сугып җибәрү. *Юра, күп уйлап тормастан, карчыкның да башына томырды. Идәндә канга батып яткан гәүдәләр аша эчкә үтеп, аннан дер калтыранган хатынны сөйрәп чыгарды.* Р.Сәгъди. *Әлеге сүзне кычкырган фермер Сәгыйдулла, Сафаларның койма тактасын йолкып алып һәм дә болгап, коммунизмның әзер шулпасын бушлай эчеп яшәгән ялкау Фәсхинең аркасына томырды.* Ф.Баттал // Йөгереп килеп сөзү. *Тәкәләрнең берсе икенчесенә --- икенче мәртәбә томырды.* М.Госманов

4) Кинәт һәм каты гына тарту. *Балыклар --- калкавычны, томырып, су төбенә алып төшеп китәләр.* А.Алиш

5) *диал.* Умыру, зур итеп кисеп, тешләп яки сындырып алу. *Каюм, зур-зур гына ике котлетны бетереп, өченчесенең читеннән томырып алгач: – Бәрәңгене кайдан аласыз? – диде.* Ш.Камал

**Томыра башлау** Томырырга тотыну. *Печәнне, өч япьле агач сәнәк белән алагаемга күтәреп, сәндерәгә томыра башлады.* Ф.Яруллин. *Егетләр таш стена артына гранаталар томыра башладылар.* Г.Гыйльманов

**Томырып җибәрү** Кинәт томыру. *Менә, ичмасам, авылда бар иде Мотгәрәйләрнең мунчасы! Ут кебек кызган ташына бер чиләк салкын су томырып җибәрсәң, ләүкәдә түгел, идәндә дә чыдар хәл калмый иде.* Ш.Бикчурин

**ТОМЫРЫК** *с.* 1) Агымсыз, хәрәкәтсез. *Томырык күлдә корт уйнар.* Мәкаль

2) *күч.* Тынчу, бөркү. *Томырык өйдә тын тарыгыр.* Мәкаль

**ТОМЫРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **томыру**

2) *к.* **томылу**. *Сыртындагы җан иясен тәгәрәтеп төшереп калдырырга теләп, Болан әле томырылып чапкан, әле кинәт туктап калган.* Ф.Яруллин. *Ул бер омтылыш белән гармунны умырып алды һәм тышка томырылды.* А.Хәлим

**ТОМЫРЫЛЫП** *рәв.* Мөлдерәп, тутырып. *Партком секретаре күзлеген җәһәт кенә йолкып алды да томырылып күзләремә карады.* М.Хәсәнов. *Камилнең томырылып үзенә карап торуын күреп, кыз, чытлыкланып, аның янына ук килеп басты.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Томырылып торган** Тутырып, мөлдерәп карый торган. --- *пароходка соңгы пассажирлар булып килеп кергән озынча йөзле, ябык гәүдәле егет белән томырылып торган кара күзле сөйкемле кызны «Вера Засулич» пароходындагылар бер күрүдә хәтерләп калдылар.* Р.Туфитуллова

**ТОН** *и. гр.* 1) *муз., физ.* Билгеле бер югарылыктагы саф тавыш. *Остазы-укытучысы Заһидулла Яруллин --- Салихка күнегүләр ясата. Бармакларның йөгерек хәрәкәте, --- югары һәм түбән тоннарга күчү --- дисеңме – боларның берсе дә игътибардан читтә калмады.* Р.Низамиев

2) *мед.* Йөрәк тибешенең, пульсның хәрәкәт тавышы. *Йөрәк тоны. Күкрәк тонының тоныклануы*

3) Сөйләүченең кәефен, тыңлаучыга яки сүз предметына карата мөнәсәбәтен һ.б.ш.ны белдергән тавыш төсмере. *Менә сөйли торгач, ул, шундый ук эшлекле тон белән, үзенең өйләнергә теләвен әйтте.* Ә.Еники. *– Ә нигә син бөтен хатын-кыз да шулайдыр дип уйлыйсың әле? – диде секретарь, җитди тонга күчеп.* В.Нуруллин

4) Төс, шулай ук бер үк төснең ачыклыгы яисә куелыгы белән аерылып торган төсмере. *Кара бөдрәле чәчләрен, --- сыпыргалап, көзге алдында Игорь ак якалы күлмәген рәтли бирә, караңгы тондагы буйлы галстугын төзәтеп ала.* Ф.Яхин. *Нәүфәл Адылов математик Якушев портретын караңгы тондагы агачтан кисеп эшләгән.* Казан утлары // Картинаның, рәсемнең яки манзараның гомуми фоны. *Якты тондагы картина*

5) *күч.* Язма сөйләмдәге билгеле бер кәеф, рухи халәт чагылышы. *Табигатьне, кеше хисләрен ачык тоннарда күрә белүе лирик геройның эстетик идеалының ачык чагылышы.* Ф.Сәхаветдинова

6) *күч.* Яшәү рәвешенең билгеле бер характеры, стиле. *Кабатланудан да курыкмыйча (бу турыда сөйләү яхшы тон булып санала) әйтә алам: Владимир Семёнович Высоцкий – минем заман кешесе, һичшиксез, кабатланмас феномен ---.* Т.Әйди. *Хәтта урамда басып ашауны да начар тон итеп саныйлар иде.* Ватаным Татарстан

7) *күч.* Җыелыш, киңәшмә һ.б.га бирелгән билгеле бер юнәлеш. *Без бөтен татарның хәрәкәтенә тон бирә идек.* Г.Исхакый. *Балтыйк буе республикаларының югары культуралы депутатлары съезд һәм парламент эшенә тон бирә.* М.Галиев

**ТОНАЛЬ** *с.* Тон (*1, 4 мәгъ.*) белән бәйләнешле, тоннарга караган. *Тавыш югарылыгы – аның тональ үзгәрешләргә сәләтлелеге, ягъни диапазон киңлеге.* Ш.Асылгәрәев. *Битен ясау аңа да проблема булмады: тональ кремнар, пудралар, тушьлар, гельләр, ирен буяулары, --- тагын әллә ниләр эшкә җигелде.* Н.Көбәш

**ТОНДЫРГЫЧ** *и. тех.* Сәнәгать предприятиеләрендә, су корылмаларында һ.б.да сыеклыкны тондыру юлы белән сафландыру, тазарту бассейны яки резервуары. *Тондыргычлардан су фильтрларга керә.* Химия

**ТОНДЫРУ** *ф.* 1) Тонык хәлгә китерү, тонықландыру. *Базаркян казанны төшереп, җиде таска салып, сөтне тондырды.* К.Насыйри. *[Суны] комы, балчыгы белән тутырма, әйбәтләп тондырып ал.* Т.Гыйззәт

2) Көч белән ыргытып, атып бәрү. *Аның итәгенә мин барып ябышканыем, әлеге урыс мине күтәреп алып, айкап торып, кар көртенә тондырды.* А.Хәсәнов. *Искәндәр учына йомарлап*

*өлгергән ташын җан ачуы белән капка төбендәгеләргә тондырды.* М.Кәбиров

3) Савытка, капчыкка һ.б. сыешлыкларга нәрсәне дә булса күп итеп яисә тиз генә һәм үлчәмичә, чамаламыйча салу. *Ул блиндаж миченең утлы күмеренә куйган берничә котелокның берсен алды да шуңа бер уч чәй тондырды, өстен япты.* Х.Камалов. *«Инде хәзер киемнәрне юарга кирәк!» – диде ул һәм ваннага су агызып, шул суга ике кап порошок тондырды.* Ф.Яруллин

4) *сөйл.* Көч белән сугып җибәрү, колак тонырлык дәрәҗәдә каты итеп сугу. *Ире – Нәҗибе исенә төште, аның, шушы кискен тартыш барганда, сәкедә җәйрәп, гырлап ятуын уйлап әрнегән хатын Сабитның икенче яңагына берне тондырды.* А.Гыйләҗев. *Вилданов аның изүеннән сул кулы белән эләктереп «торырга ярдәм итте» дә уң кулының зур йодрыгы белән ияге астына китереп тондырды.* З.Зәйнуллин

5) *күч.* Күрмәс яки ишетмәс дәрәҗәгә җиткерү. *Нәкъ шул вакытта якында гына каты шартлау бар җирне селкетте, колакны тондырды.* Х.Камалов. *Гимнастёрка якаларын чишкән яланбаш Әлтафи, күзләрен тондырып, чын ау мылтыгы белән сәхнәгә атылып керде ---.* М.Мәһдиев

**Тондыра башлау** Тондырырга тотыну. *Немецлар тәмам исләрен җыйдылар, чәнечкеле тимерчыбык буена вак мина белән тондыра башладылар.* Х.Камалов. *Халык тынып калды, түгәрәк кысыла төште, һәм ике яшь егет, усалланып, бер-берсенә шап та шоп йодрык белән тондыра башладылар.* Н.Фәттах

**Тондыра язу** Чак кына тондырмый калу. *Каргасын каркылдатып колагыбызны тондыра язды...* Н.Сәйяр

**Тондырып алу** Тиз генә тондыру; кинәт, каты итеп тондыру. *Аны-моны уйламыйча, Мөнип карт кулындагы сөңгесен күтәрде дә авыр сөңге сабы белән тегенең арт санына берне тондырып алды.* Н.Фәттах

**Тондырып бетерү** Ахыргача, тулысынча, бөтенләй тондыру. *Аннары берсе өстеннән берсе миңа зарланырга тотыналар. Тәмам колагымны тондырып бетерәләр.* А.Хәсәнов

**Тондырып карау** Сынау өчен тондыру. *[Вәлиәхмәт:] Яле, тондырып кара. – Налимә, кизәнеп, Вәлиәхмәтнең битенә суга.* Т.Миңнуллин

**Тондырып ташлау** Уйламыйча тондыру. – *Минемчә, йомыркаларны күбрәк тондырып ташладык бугай, – дип, Фәрхетдин төрттереп алды.* Ш.Бикчурин. *Берсенә ялгыш ныграк тондырып ташлаганмын...* Д.Бүләков

**Тондырып тору** Әле, хәзер тондыру; һәрвакыт, даими тондыру; билгеле бер вакыт арасында тондыру. *Сугыштан соң аякка басып китә алмыйча азапландык: бераз күтәрелебрәк карасак, баш түбәсенә тондырып тордылар.* М.Хуҗин. *Әлеге химик элемент, суны бер тәүлек тондырып торган очракта, парга әйләнеп юкка чыга.* Шәһри Казан

**ТО́НЕР** *и. ингл.* Принтерда, басу аппаратында кулланыла торган буяу матдәсе

**ТОНЗИЛЛИТ** *и. лат. мед.* Йотылыктагы бадәмсыман бизләрнең ялкынсынуы. *«Ак чәчәкләр» фильмында хроник тонзиллиттан йөрәгендә тайпылышлар килеп чыккан авыру, бер табибтан икенчесенә йөри-йөри, инвалидка әйләнә.* Сөембикә. *Ангина, тонзиллит, бронхит, үпкә ялкынсынганда, бронхиттан интеккәндә, балан чәе файдалы.* Шәһри Казан

**ТОНИЗМ** *и. рус әд.* Басымнарның билгеле бер тәртип белән килүенә нигезләнгән шигырь төзелеше. *Силлабик шигырьләрнең ритмы тезмәләрнең билгеле урыннарында басымнар оештырылып килүенә (тонизмга) таяна.* Х.Курбатов

**ТО́НИК** I *и. ингл.* 1) Коктейль ясау өчен кулланыла торган салкынча, төссез, хәл кертә торган газлы эчемлек. --- *составында алкоголь бик аз булган тоник, коктейль кебек эчемлекләр сату утыз өч процентка азайган.* Татарстан яшьләре

2) Бит тиресен чистарту, сафландыру өчен кулланыла торган косметик матдә, сыекча. *Иң беренче чистарткыч күбек яки сабын белән битегезне юып, чиста тирегә – тоник, иренегезгә гигиена иннеге сөртеп куегыз.* Шәһри Казан

3) Тонусны күтәрә торган матдә; шуның нигезендә ясалган ашамлык яки эчемлек. *Аны фармацевтлар ашкайнату системасын нормага салучы хуш исле тоник дип атый*

**ТО́НИК** II *с.* 1) *әд.* Басымнарның билгеле бер тәртип белән чиратлашуына нигезләнгән. *Гомумән алганда, шигъриятtә хәзер силлабик-көйләм шигыреннән тоник шигырь төзелешенә, интонацион сөйләм шигыренә күчү көннән-көн ачыграк сизелә бара.* М.Шабаев

2) *лингв., муз.* Басым, тон, музыка һ.б.ш.га караган. *Мондый басым тоник (музыкаль, мелодик) басым дип атала.* Ф.Сафиуллина

**ТО́НИК** III *с.* Тонус белән бәйле, шуңа караган; тонусны күтәрә торган. *Ә спирт белән кофеин кебек тоник матдәләрнең бергә кушылуы кешене бәйлелеккә китерә һәм бик зыянлы.* Кызыл таң

**ТОНЛА́У** *ф.* 1) Тон бирү, кирәкле төсләргә буяу. *Бакый Урманче Хуҗа Насретдин мәзәкләренә ясаган иллюстрацияләрен нәфис төсләр белән тонлаган*

2) Автомобиль һ.б.ның пыяласын караңгылату. *Автомобильнең арткы пыяласын тонлау*

**ТО́ННА** *и. фр.* Метрик системада 1000 килограммга тигез авырлык үлчәү берәмлеге. *Студентлар да кайтып китсәләр, ындыр табакларындагы миллионнарча тонна бер дигән чи бодай дөрләп яначак.* А.Хәсәнов

**ТОННАЖ** *и. фр.* Транспорт чараларының йөк сыйдырыш күләме. *Ул куакларга совет сәүдә флоты, тоннаж буенча дөньяда алтынчы урынны алып торса да, составының яңалыгы буенча беренче урында икәнлеген аңлатты.* Р.Мостафин

**ТОННАЖЛЫ** *с.* Билгеле бер микъдардагы тонналар сыйдырышлы. *Теләсә нинди тоннажлы корабларны ремонтлый алырлык доклар, краннары, ипле пирслары бар.* А.Хәсәнов

**ТО́ННАЛАП** *рәв.* 1) Тонналарга бүлеп, тонна үлчәме белән. *Без – имам, мөфти, казыйлар – Русия, Татарстан өчен зур хезмәт куябыз. Ул эшне килолап та, тонналап та үлчәп булмый.* Р.Газиз

2) Ничәдер тонна чамасы, билгеле тоннага якын. *Авыр двигатель, тонналап арматура, ике тоннага якын цемент төягән машина, ак балчык өемен сөзеп узса, туп-туры упкынга очачак.* Р.Батулла. *Вертолётта очып килгән белгечләр капсуладан нидер бушатып ала, ләкин бер тонналап авырлыктагы аппаратны шунда ук алып китмиләр.* Римзил Вәлиев

3) *күч.* Күпләп, бик күп итеп. --- *миңа балык килолап түгел, центнерлап, тонналап кирәк.* Ә.Еники. *Киңәшне тонналап бирделәр аңа, әмма хәл конкрет эшкә барып төртелгәч, төрлечә боргаландылар, кайсы, мин кечкенә кеше, дип мескенләнеп калды.* Х.Камалов

**ТО́ННАЛЫ** *с.* 1) Бер яки берничә тоннага тигез булган, билгеле сандагы тонна авырлыгына тиң. *Мина ул – шундый шартлаткыч: утызар тонналы танкларны җимереп ташлый.* М.Мәһдиев. *Берзаман бозау иләмсез зур, бер тонналы үгезгә, көтүченең беренче ярдәмчесенә әверелә.* Р.Мостафин

2) Билгеле сандагы тонна сыйдырышлы яки шул күләмдәге йөкне күтәрә алырлык. – *Әле генә состав килде,* – *дип, урынына кире утырды Ихтыяр.* – *Егерме вагонмы?* – *Алтмыш икешәр тонналы егерме вагон.* Р.Вәлиев. *Татарстан Мәгариф министрлыгына балалар йортлары өчен Горький автозаводында чыга торган 1,5 тонналы ике йөк машинасы («полуторка») бирелгән.* Л.Шәех

**ТОННЕЛЬ** *и. ингл. к.* **туннель**. *Тимер юл тоннельгә кереп югалды, ә машина сулга – үргә менә башлады.* С.Шәрипов

**ТОННЕЛЬЧЕ** *и. к.* **туннельче**. *Тоннельчеләр әкияттәге кыя-тау тишүче батырлар кебек күренделәр безгә.* К.Фәсәхов, А.Сәлахетдинов

**ТОНУ** *ф.* 1) Сыеклыкның эчендә йөзеп йөргән каты кисәкчекләр төпкә утырып, утәкүренмәле хәлгә килү. *Бохарай әби ---, авылга кайткач, халыкка: «Мин урманда бик матур чишмәгә юлыктым. Мул сулы, үзе тәмле, болганса да тиз тона, күчик шул урынга --- », – дигән.* Х.Садри

2) Су аша күренгән шикелле томансу булу, ачыклыгын югалту. *Күк йөзе караңгылана төште, урман салкынчаланды, йолдызлар бер яктырып, бер тонып, ерактан-ерактан җем-җем иттеләр, елтырадылар.* Ф.Әмирхан. *Ул сәбәптән хәтерем сынган иде, Күңелемнең көзгесе тонган иде.* З.Шәмсетдин

3) *күч.* Череп яки башка сәбәпләр белән бозылу, төсен югалту. *Тонган йомыркадан бәпкә чыкмас.* Мәкаль

4) *күч.* Күрмәс, ишетмәс, сизмәс, тоймас яки фикерләмәс хәлгә килү. *Ул көч-хәл белән башын күтәрде, тонган бер караш белән килүчеләргә күз йөртеп алды ---.* М.Галәү. *Чәр-чәр килгәне атауга хәтле ишетелә, шуның тавышыннан Гыймайның түгел, минем колак тона иде.* Р.Вәлиев. *Малай аның өскә калыккан шәп-шәрә якты ботларына карамаска тырышты, --- баш эшләүдән туктады, тонды, бушап калды.* Р.Зәйдулла

**Тона бару** Торган саен ныграк тону, әкренләп тону. *Ике биек яр арасында бикләнеп гөпелдәгән шарлама тавышы якынайган саен, аның колаклары тона барды, һәм менә ул, ниһаять, килеп җитте.* А.Хәлим

**Тона башлау** Тону билгеләре сизелү. *Тик Тәлгать, тона башлаган ачык күзләрен каядыр текәп, аларга җавап бирмәгән.* З.Зәйнуллин. *Тизлек артканнан-арта, һава басымы үзгәрүдән Олегның хәтта колагы тона башлады.* З.Мәхмүди

**Тонып алу** Вакытлыча гына тону. *Игътибар итмәскә кирәк икән андыйларга, күз дә салмаска. Куыклары кабара да шунда ук шартлый. Андый вакытта, гадәттә, колак тонып ала.* Ф.Яхин

**Тонып бетү** Тәмам, бөтенләй тону. *Тыңлый-тыңлый колакларым тонып бетте.* Ф.Яруллин. *Кое суы тонып бетмәгән иде әле.* Г.Гыйльманов

**Тонып калу** Нинди дә булса сәбәп белән тонган хәлгә килү. *Бераздан аның коңгырт күзләре тонып калды ---.* А.Вергазов. *Тонып калган бу моң һәр йөрәктә, Яшәп калган бу моң һәр өйдә.* Л.Шагыйрьҗан

**Тонып килү** Акрынлап тону

**Тонып китү** Кинәт тону. *Ашлык бушаткан җирләргә алар кара болыттай төшеп утыралар, һавага күтәрелә башласалар, канат тавышларыннан колак тонып китә иде.* Ә.Еники

**Тонып тору** Вакытлыча тону. *Су тонып торган карлы-балчыклы урамнан лачтор-лочтыр ат кузгалды ---.* М.Мәһдиев. *Кинәт урнашкан бу тынлыктан колаклары, су астындагы кебек, берни ишетмичә тонып тордылар.* Ф.Садриев

**ТОН УГЫЛ** *и. бор.* Беренче ир бала. *Тон угылга тун тияр, актыгына ат тияр, уртанчыга ук та юк, чук та юк.* Мәкаль

**ТО́НУС** *и. гр.* 1) *физиол.* Нерв үзәкләренең һәм мускул тукымаларының, талчыкмыйча, киеренке хәлдә торуы. *Борынгы Чыңгыз ханнар, аннан соң килгән төрки ханнар, картаюдан куркып, организмның тонусын тиешле дәрәҗәдә тотар өчен, гомер ахырында гел ата чыпчык ите ашаганнар.* М.Мәһдиев. *Ул безнең хастаханәгә китерелгәндә, аның яшәү билгеләре юк иде инде. Сулышы сизелми, йөрәк тонусын тоеп булмый, кан басымы юк.* Л.Локманова

2) Яшәеш процессларының активлыгы. – *Чәй сары мәтрүшкә, шалфей, акчәчәк, эт шомырты чәчәге кушып пешерелсә, тонусны, кәефне күтәрә,* – *ди ул.* Т.Әйди

3) Кәеф, эчке рухи халәт, күңел торышы. *Менә җандагы нур биреп тора торган «лампочкалар»ын сүндерделәр. Нишләргә? Әллә, тонусны күтәрү өчен, кибет тирәсенә барып, «өч борын»га керергәме?* Ф.Садриев

**ТОНЧЫГУ** *ф.* 1) Һаваның төтен, ис, газ, тузан һ.б.ш. белән пычрануыннан яисә һава җитмәүдән сулыш кысылу, буылу. *«Тамак ачканда, файдасы бик зур», – дип, Әлтафи аңа тәмәке суырттырды. Гыйззәтуллин бер-ике суырып тончыкты да --- коса башлады.* М.Мәһдиев. *Чак кына һава керерлек бердәнбер урын – ишек астындагы ярык. Шул ярык янына ятып, чиратлашып, һава сулыйлар икән. Бу камерада көн саен берничә кеше тончыгып үлә.* Р.Мостафин

2) Тын юлына су, ризык һ.б.ш. эләгеп, суларга комачаулау. *«Порошин!» – дип кычкырмакчы иде, канына тончыкты.* Х.Камалов. *Шулай ди-ди үзе ярга*

*таба үрмәләде, абынды, су йотты, тончыкты, үзе ике кесәсенә дә балык тутырды.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Көчле кичерешләрдән кинәт тотлыгып калу, сүзеңне әйтә алмый тору. *Самавыр янында кара көеп утырган әни, кинәт тончыккан сыман, йөткеренеп алды.* С.Сабиров. *Хатын күз яшенә тончыкты.* Р.Камал

4) *күч.* Буылып, сулыш тыгылып яки батып үлү. *Теге Агыйделдә тончыккан кеше синең кемең була?* Г.Гобәй

5) *күч. туп.* Үлү. – *Сезне бит баш квестор Полоний, тончыкты ул, дигән иде. – Тончыкты ул, дидеме? – Тончыктымы, әллә дөмектеме, диде.* Р.Сәгъди

**Тончыга башлау** Тончыгырга тотыну. *Теге бичара чүпрәк төтене исенә түзә алмый йөткеренә, тончыга башлый.* М.Хәбибуллин. *--- сагындырган әче төтенне никотин сорап ярсыган үпкә күзәнәкләренә тутырам, аларны бронхларда озаграк, һаман озаграк тотасы килә, инде сулыш органнары тончыга башлый, ютәл буып ала.* Ф.Хуҗин

**Тончыга язу** Чак кына тончыкмый калу. *Авызына сөт коелган нарасый, тончыга язып, үзенең ризасызлыгын белдереп, беренче булып ыңгырашу авазы сала.* М.Хәсәнов. *Савыт-сабаларны юып куйгач, кухня өстәленең астын ачса, бурсыган, күгәргән искә тончыга язды.* Ф.Садриев

**Тончыгып алу** Кыска вакыт арасында бераз тончыгу. *Зәбир инде муеннан кереп баткан иде. Лайла өстеннән аның чем кара бөдрә чәче, акайган күзләре һәм җанварларча үкерүе генә калкып калды. Ул бернично тапкыр тончыгып алды.* З.Хәким

**Тончыгып бетү** Тулысынча, бөтенләй тончыгу; бик нык тончыгу. *Төтенгә үзем дә тончыгып беттем, кызның да күзләре яшьләнде ---.* З.Хөснияр

**Тончыгып калу** Кинәт тончыгу, ниндидер сәбәптән тончыгу. *Чынлап та пулемёт тончыгып калды шикелле.* Х.Камалов. *Тынчу, сасы мохиткә күнеккән үпкә саф һавадан тончыгып калды: башым әйләнеп китте, чак кына аңымны югалтмадым.* М.Әмирханов

**Тончыгып китү** Кинәт тончыгу. *Шуннан Кожинов сүгенеп бер төкерде дә (тончыгып кит шул шешәң белән, аннан башка да яшәрбез әле, янәсе) --- зур-зур атлап китеп барды.* Р.Мостафин

**Тончыгып кую** Кинәт тончыгу. *Бозау әнисенең эченнән чаршавы-суы белән килеп чыга, башы я тоягы белән үзе тишмәсә, тончыгып куюы бар.* Г.Якупова

**Тончыгып тору** Берникадәр вакытка, берара тончыгу. *Фәрит аның чыраена сыра сибә, теге сырага тончыгып торган арада, арка ягында Гаффарның югын абайлап, Фәрит чыгып йөгерә.* Р.Батулла

**Тончыгып яту** Озак вакытлар дәвамында тончыккан хәлдә булу. *Җәй буе шушы базда тончыгып яту бик күңелле дип беләсеңме әллә?* Ф.Яруллин

**ТОНЧЫКТЫРГЫЧ** *с.* Тончыктыра торган; авыр, пычрак. *Түбәндә янгын көчәя бугай, тончыктыргыч төтен әллә кайлардан бәреп чыга, --- рубкага тула, күзгә керә башлады.* С.Сабиров. *Башын артка чөеп, тончыктыргыч сасы эчемлекне чиксез аяусызлык белән авызына бушаткач, кулларын бутыйбутый, тыпырдап биергә тотынды.* А.Вергазов

**ТОНЧЫКТЫРУ** *ф.* 1) Сулыш юлын кысу, буу яки гомумән сулышны токтарлау. *Чиксез тузан тончыктыра, тын алу авырлаша, хәл бетә.* М.Гафури. *Мин сине, теләсәм, коры һавада да тончыктырам, дидем.* Н.Гыйматдинова

2) Буып, сулыш юлын каплап үтерү. *Дьяк Дмитрий исемле бу сабыйны бәкедә тончыктыра.* Р.Батулла. *Бу җан ияләрен сулы чиләктә тончыктырып үтерделәр.* Г.Гыйльманов

3) *з.-сыз* Әйләнә-тирәдәге табигый халәт тәэсирендә тын кысылу. *Ак томан ак мамык шикелле биткә, өскә сарыла, күз алдында да сыек сөт, сыек пар: буа, тончыктыра.* Р.Камалов. *Белсәгез иде андагы печән тузанын. Борынга, авызга гына түгел, колак тишекләренә хәтле тула иде. Төчкертә, йөткертә, тончыктыра.* Р.Ганиев

4) *күч. туп.* Дөмектерү, һәлак итү. *Мирхас яз көне Берлиннан махсус килгән бер снайперны тончыктырды.* Х.Камалов. *Андый әйбәт кешеләрне үтергәнче, әнә, Хәбир бабай әйтмешли, председатель Самат шикелле --- адәми затларны тончыктырасы иде дә бит.* В.Нуруллин

**Тончыктыра бару** Булган берсен рәттән тончыктыру. *Безгә хәзер астыртын рәвештә ватарга, астыртын рәвештә җимерергә, җае туры килү белән һәрбер фашистны тончыктыра барырга кирәк.* Т.Гыйззәт

**Тончыктыра башлау** Тончыктырырга тотыну. *Карале, Түбән Кама төтеннәре айга хәтле күтәрелә икән, тончыктыра башлады.* Ватаным Татарстан

**Тончыктыра язу** Чак кына тончыктырмый калу. *Аракы Шурикның ирен читләреннән акты, бугазыннан үтмичә, тончыктыра язды.* Х.Ширмән

**Тончыктырып бетерү** Барысын да тончыктыру. *Татар халкы фронтовикларга язган хатында, шулар җөмләсеннән мин дә, «--- изге Ватаныбыз туфрагына аяк баскан актык фашист шакшысына кадәр тончыктырып бетергәнче сугышырга» өндәп, барлык татар егетләрен чакырган идек.* Т.Гыйззәт

**Тончыктырып тору** Даими тончыктыру; хәзер, әле тончыктыру. *Абзарның салам түбәсе астына яшеренгән Сәлим кызарышып мунчадан чыккан бер фашистны тончыктыра торды.* Яңарыш

**ТОНЫК** *с.* **1.** 1) Тонган, саф, үтәкүренмәле. *Таймас су астында алтмышка тикле саначанчы тора, тоник суда күзен ачып, төптән унбиш адымнар үрмәләп бара ала икән.* А.Тимергалин. *Өнсез-хәрәкәтсез таулар, тып-тын, бер дулкынсыз яткан тонык күл, аның ярын басып алган биек, калын урман --- – болар барысы да аңа читсенеп, өнәмичә карыйлар.* Д.Булатова

2) Якты һәм ачык булмаган, күзгә ташланмый торган. *Ай үзенең саф, тонык нурын безнең өчен коя.* Г.Ибраһимов. *Шул вакыт өй ишеге ачылганны ишетәм һәм өйалдындагы керосин лампасының тонык нуры безгә таба юнәлгәнен күрәм.* М.Мәһдиев

3) Ачык ишетелми торган. *Кемнәрнеңдер үзара сөйләшкән тонык тавышлары ишетелде.* М.Галәү. *Әллә кайдан*

*ерактан тонык кына җыр – моңлы татар җыры ишетелә.* Г.Әпсәләмов

4) Формасы яки контурлары ачык күренми торган. *Һидиятулла картның --- саргайган, таушалган карточкасы бар иде. Шәһәр фотографы шул тонык рәсемнән могҗиза ясады ---.* М.Мәһдиев. *--- кайчандыр бу идәннең паласларын хәзер инде йөз чалымнары тонык фоторәсемнәрдә генә сакланып калган кешеләр таптап йөргәндер.* М.Маликова

5) Төсе ачык, җете булмаган. *Күк йөзе күксел бәрхеткә охшаган йомшак бер тонык төскә керде ---.* Ә.Еники. *Пәрдә аша төшкән ут палатадагы бар нәрсәне яшел итеп күрсәтә, авыруларның йөзләре дә, өсләренә ябынып яткан одеяллары да, хәтта аларның чәчләре дә ниндидер тонык яшел төскә кергән.* Ф.Яруллин

6) *күч.* Төссез, хиссез. *Аның күз алмалары --- төссез, тонык иде. Әмма шул тонык карашта ниндидер теләк дип әйтимме, ниндидер өмет димме, ниндидер омтылышмы – шуңа охшаш сәер чаткы чагылып китте.* Р.Батулла

7) *күч.* Анык, аңлаешлы, ачык булмаган. *Ләкин күңел көзгесендә аларның сурәтләре тонык ---.* А.Тимергалин. *Һәм төштәге күренешләр ачык түгел, тонык һәм төссез булалар.* И.Хуҗин

8) *күч.* Сүлпән, боек. *Яңгырга чыланган өйләрнең тәрәзәләре тонык күңелсезлек белән карап торган төсле күренә иделәр.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Күренер-күренмәс хәлдә, ачык түгел. *Өйләр, өй буендагы тупыллар, урамга кунаклаган каз оялары болганчык су төбендә утырган кебек тонык кына булып күренә башлады.* Л.Ихсанова. *Тавыш килгән яктан, тонык кына булып, әтинең шаулəсе шәйләнде бераздан.* Р.Мөхәммәдиев

2) Өлешчә канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә, уртача, яртылаш. *Либреттода Закир [образы] тонык бирелгән.* М.Җәлил

3) Ишетелер-ишетелмәс дәрәҗәдә. *Калын стена аркылы музыка тонык кына ишетелгәнгә, аз гына да борчымый.* Г.Әпсәләмов. *Ерактан, бик ерактан тонык кына ишетелә башлаган чаң тавышы да аларга баштарак шул сихри мәхәббәт чыңы булып тоелды.* Г.Гыйльманов

**ТОНЫКЛАНУ** *ф.* 1) Тонып китү, тону; ачыклыгы, җетелеге югалу. *Менә ул поезд урманга кереп китте, менә аның тавышы тоныкланды, менә ананың төпчек улы карлы туган җиргә аяк басты.* М.Мәһдиев. *Берничә елдан аларның төсе тоныклана, күбәләкләр үзләренең матурлыкларын һәм җәлеп итү сәләтен югалталар.* Ә.Халидов

2) Үтәкүренмәлегә әйләнү, ачыклану. *Күктәге балкыш кабынып яисә сүнеп киткән чагында, күл өсте дә үзгәрә: я яктыра, я тоныклана.* Г.Әпсәләмов

3) Сиземен, сизгерлеген югалту. *Саҗидәнең куллары, Сафаның иңбашыннан шуып төшеп, сәкегә бәрелделәр. Күзләре тоныкланды, аннары бөтенләй йомылды.* М.Галәү

4) Уй, фикер йөртү сәләте кимү. *Әбу Бәкер әс-Сыйддыйк бу төшеннән куркынып уянды. Маңгае тирләп чыккан, акылы тоныкланган, хәтере чуаланган иде.* Ф.Яхин

5) *күч.* Аныксызлану; көчен, конкретлыгын, җанлылыгын югалту. *[Торып киткән җир] башта сагындырып йөдәтә, яңадан барасы килеп китә, аннары, вакыт узу белән, әкрен генә ераклаша, тоныклана ---.* Ә.Еники. *Гадәттә, районга киткәч, әйбәт кенә шагыйрьләрнең дә иҗатлары тоныклана, ә Харрас районда түл җыеп яткан булды.* Ф.Яруллин

**Тоныклана бару** Торган саен тагын да тоныклану. *Кыска чәчле малай образы әкрен-әкрен тоныклана барды.* Л.Ихсанова. *Дөресен генә әйткәндә, мәхәббәт хисе үзе дә тоныклана бара кебек.* М.Әмирханов

**Тоныклана башлау** Тоныклану ягына үзгәреш сизелү. *Хәтердә тоныклана башлаганчы, кәгазьгә төшереп каласы иде бу күренешне – салават күперенең туып килгәнен.* М.Маликова. *Шунда тирә-яктагы урманнар, елтыр сулы елга, шалашлар, йөнтәс адәмнәр, ничектер, ераклаша, тоныклана башлады.* Р.Фәизов

**Тоныклана төшү** Бераз тоныклану. *Шулай да балкып торган нурлы күзләренең бераз тоныклана төшүенә дә игътибарсыз калалмады.* Г.Галиева. *Әйтерсең лә ул йөрәгендә гел генә ниндидер төзәлмәс яра саклаган, шул ярадан йөз нуры тоныклана төшкән...* Н.Хәсәнов

**Тоныкланып бетү** Бөтенләй тоныклану, тоныкланган хәлгә килү. *Стенада эленеп торган --- сәгать, тоныкланып беткән көзге --- бүлмә дивары белән бер яшьтә кебек тойгы калдыралар --- иде.* Ф.Яхин. *Күзеңне ачыбрак кара: саргаеп, тоныкланып беткән ич инде бу кәгазьләр.* А.Гыймадиев

**Тоныкланып калу** Ниндидер бер эш, сәбәптән тоныклану, тоныкланган хәлгә килү. *Аның битләре, күз кабаклары шешенеп чыккан, хәтта күзенең зәңгәрлекләренә хәтле тоныкланып калган шикелле иде.* В.Нуруллин. *Ә --- кояш, җил искән саен гаҗәеп зур утлы күмердәй кызара да, яңадан күксел элпә белән капланып, тоныкланып кала.* Р.Вәлиев

**Тоныкланып китү** *к.* **тоныклана төшү**. *Ләкин күзләрдәге элеккеге наз бераз гына кимегән, күзләр тоныкланып киткән, карашларда ниндидер серлелек, яшерен сагыш бар.* М.Мәһдиев. *Элегрәк язылган бик күп әсәрләр дә шушы фонда тоныкланып китте шикелле.* М.Галиев

**Тоныкланып тору** Вакытлыча тоныклану; тонык хәлдә булу. *Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый: йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора.* Ә.Еники. *Дөнья нәфис бәс энәләре белән нәкышьләнгән, кояшның яктысы кайдадыр еракта тоныкланып кына тора.* Ф.Садриев

**ТОНЫКЛЫК** *и.* Тонык булу сыйфаты. *Кайчандыр утлы күмергә охшап янган күзләрендә салкын, сүлпән тоныклык.* Н.Хәсәнов. *Җәй көне ул алтын нурлар койса, хәзергесе көмеш аклыгы, тоныклык хәтерләтә.* С.Поварисов

**ТОП** I *и. ингл.* Иң яхшы яки иң популяр әсәрләр (гадәттә 10–20 урынга кадәрге) исемлеге

**ТОП** II *и. ингл.* Гадәттә пиджак, блузка кебекләр белән яки үзе генә киелә торган кечкенә юка кофта. *Баксаң, тик яткан яулыклардан мәнә дигән*

*топ, --- сарафаннар да ясап киярга мөмкин икән.* Кәеф ничек?

**ТОП-** I *ингл.* Кушма сүзләрдә «иң яхшы яки иң популяр» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *топ-менеджер, топ-модель*)

**ТОП-** II *кис.* [т] авазына башланган кайбер сыйфатларга ялганып, шул сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Күлнең суы топ-тоньк.* Д.Каюмова

**ТОПАЗ** *и. гр.* Силикатлар төркемендәге төсле пыяласыман кристаллары булган минерал, асылташ. --- *кояш әлегә күренми, тиздән аның тәүге алтын нурлары бәллүр урман эченә сибелерләр дә каеннарның бәскә төренгән бөдрә ботакларыннан тамып торган ак мәрҗәннәрдә, серле топазларда чагылып уйный башларлар.* Г.Әпсәләмов. *Тышлыгы фирүзә, мәрҗән, --- топаз кебек кыйммәтле ташлар --- белән бизәлгән Коръән, үзенең зәвыклы эшләнеше белән, фото һәм видеокамераларны шундук үзенә юнәлтте.* Р.Шакир

**ТО́ПКА** *и. рус* Мич, пар казаны һ.б.ш.ның ягулык камерасы; утлык. *Күрәсең, кызу үтәр өчен, паровоз топкасына гел күмер ташлап барырга кирәктер, күмер ташлагач, морҗадан төтен белән бергә чаткылар да оча торгандыр.* Ә.Еники

**ТОП-МЕ́НЕДЖЕР** *и. ингл.* Предприятие, банк, компания яки шуның бер бүлеге белән югары профессиональ дәрәҗәдә идарә итүче хезмәткәр. *Моңарчы топ-менеджер, топ-модельләргә сокланган кебек, без тора-бара топ-слесарьга да сокланып карарбыз, ахры.* Мәдәни җомга

**ТОП-МОДЕЛЬ** *и. ингл.-фр.* Профессиональ баскычның иң югарысында торган, эш хакы бик югары булган модель, манекен. *Кирәк икән, булам горур кыз. Шаярам һәм чаяланам кайчак: Я топ-модель булам, я йолдыз.* С.Әхмәтҗанова

**ТОПО́ГРАФ** *и. гр.* Топография белгече. *1936 елда авылга Ленинград хәрби округыннан җибәрелгән хәрби топограф Мөбарәкшин хәрби карта ясау белән шөгыльләнгән.* Ф.Гарипова

**ТОПОГРА́ФИК** *с.* 1) Топографиягә караган. *Виктор Харищенко исә топографик отряд эшчесе.* И.Хуҗин. *Ул XIX гасыр ахырында Үзәк һәм Көнчыгыш Африка буйлап сәяхәт итә, --- топографик эшләр үткәрә, гидрологик һәм метеорологик күзәтүләр алып бара.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) Җир өсте үзенчәлекләрен күрсәткән. *Картадан карыйм (ә топографик карта бик төгәл: хәрбиләр өчен эшләнгән, һәр чокыр, һәр калкулык ачык билгеләнгән), әһә, безнең маршрутта ике авыл бар икән!* Р.Фәйзуллин

**ТОПОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Геодезиянең җир өстен үлчәү һәм планга яисә картага төшерү белән шөгыльләнә торган бүлеге. *Хәрби әзерлек дәресләре дә безнең теңкәгә тиде. Атнасына сигез сәгать буе һәртөрле уставлар, сугыш кораллары, тактика, топография, стройда йөрү.* Ә.Рәшит

2) Берәр урынның, җирнең, өлкәнең җир өсте (рельеф үзенчәлекләре, юллары һ.б.)

**ТОПОЛО́ГИЯ** *гр.* Математиканың деформацияләнмәгән (үзгәрмәгән), формасын саклаган геометрик фигураларның иң гомуми үзенчәлекләрен өйрәнә торган тармагы

**ТОПО́НИМ** *гр. лингв.* Нинди дә булса төбәк, урын атамасы. *Кайбер очракларда топонимнарның рус телендә кабул ителгән формасы аның борынгы, ягъни дөрес төзелешен күбрәк һәм озаграк сакларга мөмкин.* Х.Садри

**ТОПОНИ́МИК** *с.* Топонимикага караган; топонимика белән бәйле

**ТОПОНИ́МИКА** *и. гр.* 1) Берәр төбәк, өлкә һ.б.ш.ларның географик атамалары җыелмасы. *Быел мин үзебезнең районның шактый авылларында булып, андагы топонимика белән танышып йөрдем.* Т.Миңнуллин

2) Лексикологиянең географик атамаларны өйрәнә торган бүлекчәсе. *Шуннан соң татар ономастикасы, аның антропонимика, топонимика, гидронимика һәм этнонимикага багышланган томнары булачак, фразеологиягә аерым том багышланыр дип күздә тотыла.* Р.Фәттахова

**ТОПОНИМИСТ** *и. рус* Топонимика белгече. *Географик атамаларның татарча һәм русча бирелешен фәнни яктан эшләнгән принциплар нигезендә төзәтү топонимистлар алдында торган мөһим мәсьәлә булып кала килә.* Л.Шәрифуллина

**ТОПОНИ́МИЯ** *и. гр. к.* **топонимика** (*1 мәгъ.*). *Борынгы топонимиядә -улы/-олы иҗекләренә тәмамланган исем-атамалар да очрый.* Н.Фәттах

**ТОРА** I *и. диал.* 1) *бор.* Мәҗүси потханә, табыну урыны

2) Кала, кальга, шәһәр. *Шуның өчен ул бөтен ыруы белән гарәп иненә күчәргә, Суар торада мәчет, мәктәп салдырырга сүз бирде.* Н.Фәттах

3) Кальгаларны сугышып алуда кулланылган күчерелмәле башня, күчерелмәле манара

**ТОРА** II *кис.* Бөтенләй, бөтенләе белән. *Тора ят кеше түгел ич [ул], әйдә [сыер] үзебезнекенә китсен.* Ш.Камал

**ТОРА́-БАРА** *рәв.* 1) Вакыт үтү белән, беркадәр вакыт үткәч. --- *тора-бара үзем дә сизә башладым: минем уйнавым чынлап та көннән-көн яхшыра, шомара бара иде.* Ф.Әмирхан

2) Әкренләп; бераз күтәреп; җайлап. *Офык читендә бер нокта күренде, тора-бара бу нокта зур булды, һаман алга үрелде.* А.Алиш. *Баштарак өмәчеләр әкрен урдылар, тора-бара эшкә күнегеп китеп, чын мәгънәсендә ярышып эшли башладылар.* М.Галәү

**ТОРАК** *и.* **1.** 1) Яшәү, тору өчен эшләнгән бина, бүлмә яки корылма. *Казан дәүләтенә кергән төньяк-көнбатыш Башкортстанның урман полосасында яшәгән игенче халкында күрше халыкларныкына охшаш агач тораклар булган ---.* Б.Хәмидуллин. *Теге әбине бүген үк шул йортларның берсенә урнаштыра тор, ятим балаларны да иске торакларыннан күчерергә кирәк булыр.* Ф.Хуҗин

2) *к.* **торлак** (*1 мәгъ.*). *Көзге кырпак төшүгә, бөтен Болгар иле яңадан үзенең кышкы торак урынына – Чулман белән Чирмешән арасындагы болыннарга кайтып керә иде.* Н.Фәттах

3) *к.* **торлак** (*2 мәгъ.*). *Шушы урында --- ашханә, склад, клуб, ферма*

*тораклары салынды*. Ф.Садриев. *Терлек тораклары искиткеч зур, нык итеп төзелгән, артезиан коеларыннан су бина эченә үк кертелгән иде*. Т.Нәҗмиев

**2.** *с. мәгъ.* Кеше яшәрлек, кеше яши торган. *Моңарчы шәп-шәрә дала булып яткан җирләрдә яңа торак пунктлар, посёлоклар калыккан.* А.Хәсәнов. *Асяның анда торак бүлмәсе бар.* Х.Камалов

**ТОРАКЛЫК** *с.* **1.** Торак булырлык, тору өчен яраклык, кеше яшәрлек. *Беркөн ул [Нигъмәтҗан] Мәүлиха әбинең исән калган ярты өен тәмам тораклык хәленә китерде.* Ә.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ.* Торак, торак корылмалар массивы (бина, авыл, шәһәр һ.б.). *Еракта тораклыклар күренеп тора. Аның бик күп җирләрдә станнары, тораклыклары, кирмәнчекләре, шәһәрчекләре булган.* Татарстан тарихы

**ТОРАКХАНӘ** *и.* Торак бүлмә яки торак йорт, торак мәйдан. *Патша торакханә каравылчысын да, буяуханәдәге эшчеләрне дә сарайга чакырта, алардан Әбү Сыйр турында сораша.* Әкият

**ТОРАТАШ** *и.* 1) Табыну максаты белән вертикаль рәвештә урнаштырылган зур таш пот, балбал, санәм. *Уттай янган дүрт күз, тораташка, потка текәлгәндәй, куркып, ялварып, түрдә утырган ханга текәлде*. Н.Фәттах

2) Җир өслегеннән өскә чыгып торган зур һәм биек таш, кечкенә кыя; борынгы халыклар урнаштырып калдырган зур таш; башбата. *Мондый кешеләрне ачуландыруы чиксез кыен. Алар тау башында җиргә кереп беткән торадашка охшыйлар.* Г.Әпсәләмов

◊ **Тораташ булып калу** *к.* **тораташ булып кату**. *– Вон моннан, Мөхәммәтгали углы Сираев! – Кунак, аптыраптаушап, тораташ булып калды, ул ни әйтергә белмәстән: – Нәрсә? – диде.* Р.Батулла. **Тораташ булып кату** Берәр төрле көчле кичерештән, гаҗәпләнүдән, аптыраудан һ.б.ш.дан хәрәкәтсез калу. *Мин инде китеп барырга да җыенган идем, Хәкимҗанның тораташ булып катып торуына гаҗәпләнеп, туктап калдым.* Г.Бәширов. *Бу көтелмәгән хәлдән алар да тораташ каткан иде.* Г.Әдһәм. **Тораташка әйләнү** *к.* **тораташ булып кату**. **---** *Нәгыймне астан тартып чыгарган Әнис абый, бер мәлгә, үле гәүдәне нишләтергә дә белмәгәндәй, чайкалып басып торды да, тораташка әйләнеп, телдән язган Хәким абыйның беләгенә китереп салды.* Н.Гыйматдинова. **Тораташтай катып калу** *к.* **тораташ булып кату**. *Әкрәм карый гаҗәпләнүдән тораташтай катты да калды.* М.Галәү. *Баш хадим --- җарияләрне олы залга чыгарып тезгән иде, сарайда күптән түгел генә пәйда булган Роксолана авызыннан шундый сүз ишетеп, тораташтай катып калды*. В.Имамов

**ТОРАЧЫ** *и. диал.* Уртак бабадан соң бишенче буын вәкиле булган хатынкыз. *Торачы түтәй*

**ТОРА ЯТ** *и. иск.* Уртак бабадан соң бишенче буын вәкиле (2 нче буын – **туган**, 3 нче буын – **тума**, **тумача**, 4 нче буын – **туа ят**)

**ТОРБА** I *и.* 1) Сыеклык, газ, пар һ.б.ш.ны үткәрү өчен эче куыш озын көпшә, көбәк, морҗа. --- *усал җил йортлар арасында тырпаеп калкып торган торбалардан ургылган кара төтенне өзгәләп очыра иде*. М.Маликова. *Аккан суын җир астына күмелгән тимер торбалар аша дуңгыз фермасына төшерттергән иде. Торбалары тыгылгач, үз агымына агып торган чишмә бөтенләй тукталды.* Н.Хәсәнов

2) Судноның машина бүлегенә боерыклар, күрсәтмәләр бирү өчен көйләнгән махсус көпшә. *Капитан нечкә торба аркылы түбәндәгеләргә кычкырды*

3) *сөйл.* Йөрәк тибешен һәм сулыш алуны тыңлау җайланмасы; стетоскоп. *Торба белән тыңлау кирәкме, чүкеч белән төпелдәтү кирәкме, кроватька яткырып әвәләү кирәкме – берсен дә калдырмады доктор.* М.Әмир

4) Бер башы бүрәнкәсыман киңәйгән тынлы музыка коралы. *Егетләр яшь: кайсы тугызда, кайсы унда укый ---. Үпкәләрен бераз ял иттергәч, ирennәрен юешләп, яңадан торбага өрә башлыйлар. Ярты сәгать чамасы өргәч, композитор туктата, төзәтмәләр кертә ---.* М.Мәһдиев. *Иртәнге якта бар кешене мәйданга кудылар, анда, кызыл байраклар болгап, җиз торбалар уйнатып, кайнар нотыклар сөйләп, мичне өрдереп җибәрделәр.* Ф.Бәйрәмова

5) *физ.* Ерактагы предметларны күзәтә торган оптик прибор. *Кораблар ярга мөмкин кадәр якынрак килделәр ---. Күперчекләрдәге шкиперлар озын-озын күзәтү торбаларын бушап калган яр буена, урман читләренә, ерактагы тауларга төбәделәр.* И.Хуҗин

**ТОРБА** II *и.* Юлда йөргәндә, атка азык салып бирү өчен тегелгән махсус капчык (җигелгән атның башына кидерелеп куела). *Буш торба белән ат тотылмас.* Мәкаль. *Торба төбен иснәмичә ат туймый.* Мәкаль

**ТОРБА́КИСКЕЧ** *и. тех.* Металл трубаларны кисә торган корал, пычкы

**ТОРБАЧЫ** *и.* 1) Торбада I (*4 мәгъ.*) уйнаучы яки сигнал бирүче музыкант. *Скрипкачы чикерткә, кубызда уйнаучы май коңгызы, торбачы күбәләк, барабанчы әкәм-төкәм һәм башка музыкантлар шунда җыелганнар.* Җ.Тәрҗеманов

2) Торба I (*1 мәгъ.*) салучы, торба үткәрүче эшче. *Алар, командировкаларга барып, --- бораулаучылар, ташчылар, шофёрлар, торбачылар белән аралаштылар һәм шулар тормышы турында яздылар.* Р.Фәйзуллин

**ТОРГАНЫ** *рәв.* 1) Гел, һаман, һәрвакыт. *Әти торганы: «Балаларым яшь кала», – дип өзгәләнде.* Г.Гобәй

2) Бөтенләй, баштанаяк. *Егет кенә түгел бит ул минем Мусам, аның торганы алтын.* Ф.Бурнаш. *Баланың, чынлап та, кызыксынып карарлык җире юк иде. Торганы бер юешлектән гыйбарәт иде ул.* М.Әмир

**ТОРГИ** *и. рус сөйл.* Берәр кешенең, учреждениенең һ.б.ның мал-мөлкәтен яисә кайсы да булса сирәк әйберне, сәнгать әсәрен, махсус игълан итеп, халык алдында артыграк хак бирүчегә сату; ачык базар, аукцион. *Шәһәр торгиенда Воронцовларның Өчтамак пристанендагы икмәк конторaларын сатып алдым.* Т.Гыйззәт. *Вакытында түләнмәгән налог өчен авыл җитәкчеләре фәлән әйберне алып чыгып китәләр дә шуны «торги»га куеп саталар ---.* М.Мәһдиев

**ТОРГЫЗУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тору**. *Любашаны үз яныбызда гына торгызасы иде, әмма без теләгәнчә булмас шул.* М.Хуҗин

2) Аякка бастыру, торырга, басарга ярдәм итү яки мәҗбүр итү. *Мин, бер сүз әйтмичә, бары: «Әйдәгез!» – дип, аны кулыннан йомшак кына тотып торгыздым.* Ә.Еники. *Шулай бер әүмәкләшеп алгач, үземне кар эченнән күтәреп торгыздылар ---.* Л.Ихсанова

3) Нәрсәне дә булса тек, вертикаль, үрә торган хәлгә китерү, бастыру. *Атым муенын катырган, колакларын торгызган.* Г.Бәширов. *Гайфулла куштан --- толып якасын торгызган, авызыннан котырган сыер сөте исе бәрелеп тора.* М.Мәһдиев

4) Нәрсәне дә булса төзү, ясау. *Куллар арасында, сазлык кырыйларында, кыя башларында әйләнә-тирәне ут астында тотарлык яңадан-яңа ныгытмалар торгыздылар.* Г.Әпсәләмов. *Янган кешеләргә йортлар торгыздылар, Кармаш хастаханәсенә мунча салдылар.* М.Маликова

5) *диал.* Берәр урында тоту (күбесенчә кыска вакыт эчендә). *Хөснетдинне, бер-ике сәгать келәттә торгызып, тагын милиция бүлмәсенә чакырдылар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

6) *дини* Тиешле хәрәкәтләрен үтәп, тиешле сүрәләрне, тәсбихләрне әйтү; кылу, уку (намаз тур.). *Берсе намазда, ә икенчесе әлегә намазын торгызмаган булса, ай-һай, тормышта авыр.* Сөембикә. *Анда: «Намазны торгызыгыз, дөреслектә, намаз мөселманнарга билгеле вакытларда үтәлергә тиешле гамәл итеп йөкләтелде», – дигән.* Шәһри Чаллы

7) Йокыдын уяту. *Иртәнге алтыда йокыдан торгызалар.* Р.Мостафин

8) *күч.* Җимерелгәнне, таркалганны рәткә кертү, яңартып җибәрү. *Сабира апасының балалары иске мәчетне яңадан торгыздылар, Зәйтуганда яңадан мәчет эшли башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Союз җимерелде. Дәүләт белән идарә итәргә, производствоны торгызырга, авыл хуҗалыгын саклап калырга, икътисадны аякка бастырырга кирәк.* Р.Миңнуллин

9) *күч.* Берәр оешма, хуҗалык һ.б.ш.ны кабат тергезү. *Яһүдләр үзләренең дәүләтен ике мең елдан соң торгыздылар.* З.Зәйнуллин

10) *күч.* Үсеп китәргә ирек бирмичә, бер дәрәҗәдә тоту. *Мәдәни үсешне кичәге дәрәҗәдә торгызу*

11) *күч.* Терелтү. *Ул кыямәт көнне үлекләрне торгызыр, һәм Аның көче бөтен нәрсәгә дә җитәдер*

**Торгыза бару** Эзлекле рәвештә бер-бер артлы торгызу. *Соңгы ике бүлектә автор татар мәдәниятенең нигезен тәшкил иткән һөнәрләргә туктала, --- аларга һәйкәл торгыза бара.* Т.Галиуллин

**Торгыза башлау** Торгызырга тотыну. *Әни аксакны бер култыгыннан күтәреп торгыза башлады.* Х.Камалов. *Гитлерчылар, шул тирәгә йөздән артык солдат урнаштырып, яңадан күперне торгыза башладылар.* И.Хуҗин

**Торгыза төшү** Гадәттәгедән ныграк торгызу. *Әрекмән яфрагыдай зур йонлач колакларын торгыза төшеп, хәрәкәтсез калды...* М.Хәсәнов. *Студентлар колакларын тагы да ныграк торгыза төшәләр.* Э.Шәрифуллина

**Торгызып бару** Һәрберсен рәттән торгызу. *Ул ике япьле агач сәнәк белән машина алдыннан егылып чуалган сабакны торгызып барырга тиеш.* М.Әмирханов

**Торгызып бетерү** Барысын да торгызу; ахырга кадәр торгызу. *Йортны һәм хуҗалыкны яңадан торгызып кына бетерәләр – сугыш башлана.* Я.Шәфыйков. *Ташчылар йорт стеналарын торгызып бетерде ---.* Ә.Сафиуллин

**Торгызып җибәрү** Билгеле бер моментта, тиз генә торгызу; яңадан торгызу. *Менә ярлылар өчен ашханәне дә торгызып җибәрәсе иде.* Ш.Баһаутдин. *Җиңү көненең 65 еллыгы уңаеннан тимурчылар хәрәкәтен торгызып җибәргәннәр.* Ватаным Татарстан

**Торгызып карау** Торгызырга тырышу. *Өйгә алып кайту өчен, атын торгызып карый, хәле җитмәгәч, бергә эчеп утырган танышларына китә.* Г.Нигъмәтуллина. *Бер елдан монополияне кабат торгызып карадылар, ләкин «идән астында» аракы җитештерүчеләрне контрольдә тотарлык түгел иде инде.* Ватаным Татарстан

**Торгызып кую** Тулысынча, тулаем торгызу. *Ә өйнең, Алла боерса, менә дигәнен торгызып куярбыз, мин андый балчык өйләрнең ничегрәк салынганын караштыргалап йөрдем инде.* М.Галәү. *Аның бәхетенә, ул тирәдәге биш-алты колхоз берләшеп, өч катлы хастаханә бинасы торгызып куйганнар икән.* М.Маликова

**Торгызып тору** Билгеле бер вакыт аралыгында торгызу. *Турыга өенә кайтып китми, Фазлый да, шунда тоткарланып, кеше сүзенә колагын торгызып тора икән.* З.Мурсиев

**ТОРГЫН** *с.* 1) Үтәли агымы булмаган, бер урында җыелып торган, агымсыз (су тур.). *Әнә бит, ургып агып торган куәтле елга, торгын сулы күл кебек, акрынлап сөрси, өсте яшелләнә, --- акрынлап һәлакәткә бара.* С.Сабиров

2) *физ.* Бер үк амплитудалы һәм ешлыклы дулкыннар бер-беренә каршы килеп кушылганда барлыкка килә торган. *Ике системаның дулкыннары, бербере өстенә салынып, торгын дулкын хасил итәләр.* Физика

3) *кит.* Бер халәттә катып калган, үзгәрми торган. *Мин үзем бик үк ышанып бетмәсәм дә, ихтимал, икенче канатны салу мәсьәләсе дә торгынноктадан кузгалыр.* Г.Әпсәләмов

**ТОРГЫНЛАШУ** *ф.* Торгын булып китү; торгынга әверелү. *Икътисадның торгынлашуы*

**ТОРГЫНЛЫК** *и.* 1) Агымсызлык, хәрәкәтсезлек (су тур.)

2) Нәрсәнең дә булса үсеше тукталу, катып калу. *Консилиумнарны еш җыю белән без врачларны үзалларына фикер йөртүдән, мөстәкыйль карар кабул итүдән, инициатива күрсәтүдән биздерәбез. --- Бу инде гариплек, медицинаны торгынлыкка илтү.* Г.Әпсәләмов. *Илдә гәрчә бүген «торгынлык чоры» дип йөртелсә дә, совет власте елларының иң чәчәк аткан, халык хуҗалыгы тотрыклы үсеш алган заман Л.И.Брежнев хакимлек иткән 1964 елдан соңгы чорга туры килә.* Р.Корбан

3) Хәрәкәтсезлек; эшсезлек, инициативасызлык. *Кырларда-басуларда –*

*сөрелгән һәм сөреләсе җирләрдә, әрәмә өсләрендә, чокыр-чакырларда, калкулык башларында – бөтен тирә-якта серле бер тынлык, торгынлык саклана иде*. Н.Фәттах. *Үзеңнең оеган буыннарыңны язу, холкың торгынлыгын җиңеп, яңарып яшәргә тырышу беркайчан да соң булмаска тиеш*. Ш.Галиев

**ТОРЕАДОР** *и. исп.* Корриданың төп катнашучысы, үгезне үтерүче. *Малайлар Хәмитнең --- цирк дигәне үгез белән булачагын тиз чамалап алдылар. --- Хәмит ишегалдыннан Акмаңгайга атланып чыкты. Кыяфәте горур, әйтерсең испан тореадоры*. Ф.Яруллин. *Бик күп тореадорлар, оста матадор булып җитешкәнче, байтак еллар бандерильеро вазифасын башкаралар*. Р.Фәйзуллин

**ТО́РИЙ** *и. лат. хим.* Сәнәгатьтә атом энергиясе чыганагы буларак файдаланыла торган көмешсу ак төсле радиоактив металл. *Кытай галимнәре аңлатуынча, шәһәрдәге йортларның барысы да диярлек уран һәм торий артык күп булган гранитлы бетоннан төзелгән*. Мәдәни җомга

**ТОРКЫЛДА́У** *ф.* Торыйк-торыйк дип кычкыру (торналар тур.). *Сандугач сайрап, карга каркылдап, торна торкылдап дан казана дигәндәй, Уймин әнә карга урынына каркылдап йөреп дан казанды тылда чакта*. С.Поварисов

**Торкылдап алу** Бераз, берара торкылдау. *Язгы зәңгәр күктә очкан торналар күл өстеннән узганда торкылдап алды*. Яңарыш

**Торкылдап кую** Көтмәгәндә, кинәт торкылдау; бер тапкыр торкылдау. *Торкылдап куйды мескен савыт, эчендәге «байлыгы»ннан аерылганда*. Ф.Баттал

**Торкылдап тору** Бертуктаусыз торкылдау; даими торкылдау

**Торкылдый башлау** Торкылдарга тотыну

**ТОРКЫЛДАШУ** *ф.* Бергәләп һәм берьюлы яки вакыт-вакыт торкылдау (торналар тур.). *Кар инде эреп бетте диярлек. Кошлар сайрый, торналар торкылдаша*. Р.Мостафин. *Поезд балаларны туган туфрактан көннән-көн ераграк алып китә. Көньякка, әле генә торналар торкылдашып киткән җылы якларга*. А.Тимергалин

**Торкылдаша башлау** Торкылдашырга тотыну

**Торкылдашып алу** Кыска гына вакыт арасында, бераз торкылдашу

**Торкылдашып тору** Даими, һәрвакыт торкылдашу; хәзерге моментта торкылдашу. *Тор-тор-торналар Торкылдашып торалар, Торганнары очып китә, Тормаганын тоталар*. Тизәйткеч

**ТОРЛАК** *и. сир.* 1) Даими яши торган урын. *Кызны теләсәм кемгә бирермен, андый торлагы юк нәрсәгә [хәлфәгә] бирмәм*. М.Гафури. *Археологларга мәгълүм булганча, борынгы ныгытылган торлаклар кору өчен табигатьнең үзе тарафыннан текә Кремль тавы кебек уңайлы булган урыннар беркайчан да буш тормаган*. Ә.Мөхәммәдиев

2) Мал-туар торагы (абзар, кура, кутан һ.б.). *Торлактагы мал – кулдагы мал, аулактагы мал – юлдагы мал*. Мәкаль

**ТОРМА** *и.* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан ак төсле түгәрәк юан яки озынча тамырлы икееллык үсемлек. *Икенче язда бөтен тирә-як шашыпшашып торма чәчә, ә булган хуҗа, алты сутыен тутырып, кишер белән кыяр утырта*. А.Гыйләҗев

2) Шул үсемлекнең әчкелтем тәмле һәм исле, ашарга яраклы тамыры. *Нәрсә ашыйсың? Пылау китеримме? Уган торма белән?* Ш.Хөсәенов

◊ **Торма өстенә тоз** Бер кыенлык өстенә икенче кыенлык, кайгы өстенә кайгы. *Торма өстенә тоз дигән кебек, тагын бер кечкенә вакыйгадан соң аларның [Вахитов белән Песнәкнең] арасы тәмам салкынайды*. С.Баттал

**ТО́РМОЗ** *и. гр.* 1) Кайсы да булса транспорт берәмлегенең хәрәкәтен бөтенләй туктату җайланмасы. *Нурсөя хәзер бу машинадан артта калу өчен тормозга басты*. Ф.Яруллин. *Көймә очында утырган кыз, ялгышлык белән, тормоз булып хезмәт иткән җайланманы ычкындырып җибәргән икән бит*. Н.Вахит

2) *күч.* Комачау, киртә, тоткарлык. *Бик күп беләсең икән, тот та: «Грязнов татарларны кыса, эшкә тормоз ясый, аның урынына мине куегыз», – дип, директорга заявление бир*. Г.Кутуй. *Эшләргә дисәң, кеше юк. Ә ул, проблеманы хәл иткән чакта, тәгәрмәчкә таяк тыгып, тормоз ясап тик тора*... Л.Лерон

3) *күч.* Башы эшләми, әйткән фикернең мәгънәсен тиз аңлый алмый торган кеше

**ТО́РМОЗЛАГЫЧ** *с.* Тормозлый, тоткарлый торган. *Тормышта тормозлагыч факторлар шактый*

**ТО́РМОЗЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тормозлау**

2) *күч.* Эчке тоткарлыклар тәэсире нәтиҗәсендә әкренәю, авырлашу, кыенлашу. *Төрлесен уйлап баш ватам, уйлау сәләтем тормозланудан тагын маңгаема тир бәреп чыга*. Т.Әйди

**Тормозланып бетү** Тәмам, бөтенләй тормозлану; тормозланган хәлгә килү. *Аптыраудан гаҗиз булып утыра торгач, тормозланып беткән акылымда бер-ике сорау туды ---*. Ф.Баттал

**ТО́РМОЗЛАУ** *ф.* 1) Транспорт чарасының хәрәкәтен берәр механизм яки җайланма белән әкренәйтү яки бөтенләй туктату. *Әгәр полосаның бер кырыена эләккән булсак, тигезсез тормозлау нәтиҗәсендә самолётны бетоннан чыгарып атарга мөмкин*. Р.Ибраһимов. *Үз алдыгыздагы гына түгел, артыгыздагы дистанцияне дә контрольдә тотыгыз: чак кына тормозга басып алыгыз, тормоз утлары яна һәм арттагы машина йөртүче дә тормозлый*. Биектау хәбәрләре

2) *күч.* Әкренәйтү, тоткарлау, авырайту, кыенлаштыру

**Тормозлап алу** Вакыт-вакыт яки урыны-урыны белән тормозлау

**Тормозлый башлау** Тормозларга тотыну. *Мондый участокларга якынлашканда, алдан ук тормозлый башларга кирәк*. Биектау хәбәрләре

**ТО́РМОЗЛЫ** *с.* Тормозы булган

**ТО́РМОЗСЫЗ** *с.* 1) Тормозы булмаган, тормоз белән тәэмин ителмәгән. *Аларның тормышы рельслардагы поезд яки колеяга эләккән тормозсыз машина шикелле тәгәри дә тәгәри, тәгәри дә тәгәри*. Х.Мөдәррисова

2) *күч.* Артык тәвәккәл, бөтенләй курку белми торган

3) *күч.* Тотнаксыз. *Бу кыз тормозсызга охшап тора*

**ТОРМЫШ** *и.* 1) Кешенең җәмгыятьтә яшәү хәле, яшәве; хәят, яшәеш, тереклек. *Акыллы, гадел, тормышның ачысын-төчесен хәтсез татыган Гөлниса апа кызына гына ишетелерлек итеп болай диде ---.* М.Хәсәнов. *Казан арты җирләре Болгар дәүләте составына кергән һәм иҗтимагый тормышта әһәмиятле роль уйнаган.* Ф.Гарипова

2) Чынбарлык. *Сөйлисем килгән вакыйга, чыннан да, тормышта булган хәлләрдән, һәм алар кешеләрнең ниндилеген, кемлеген аңлар өчен файдага ярарлык мисаллардан кебек тоелдылар.* Ф.Яхин. *Ата-бабаларыбыз киемне үз гореф-гадәтләре һәм зәвыкларына туры китереп кабул иткән, аннан соң, тормыш таләпләреннән чыгып, үзенчә яңарткан.* Сөембикә

3) Яшәү, тереклек итүнең билгеле бер иҗтимагый тирәлек шартлары. *Иске тормышны үтәли чәнчеп алырбыз, Алырбыз да яхшы гына җир астына салырбыз.* Һ.Такташ. *Ә соңынтын Тугаш карт авыл тормышының, җир кешесенең, бер яктан, искиткеч гади, икенче яктан карасаң, баш җитмәслек хикмәтле, фаҗигале икәнен, озак кына тавыш-тынсыз калып, тагын да тирәнрәк аңлата төште.* Ә.Баян

4) Шәхеснең җәмгыятькә мөнәсәбәтле рәвештә, җәмгыять эчендә формалашкан яшәү үзенчәлеге. *Гөлшәһидә Маһирә ханымның шәхси тормышын бик аз белә иде.* Г.Әпсәләмов. *Фәритнең, гаилә тормышы саф мәхәббәткә корылырга тиеш, дип дәгъва итүенә әйләнә-тирәдәгеләр ниндидер бер кылану дип кенә карыйлар.* А.Расих

5) Яшәүнең матди шартлары, билгеле көнкүреш рәвеше. *Сүзне ул бик ерактан башлады: ике ыруның борынгыда бер-берсенә кардәш булуларын, элекке иркен тормышны, Ак хан, Кара хан турындагы бабайлар сүзен – барысын да искә төшерде ---.* Н.Фәттах. *--- симезлек мул, тәрбияле тормыш билгесе түгел, киресенчә, чама белмәү билгесе дип табылды.* Сәламәт булыйк!

6) Гомер, язмыш. *Эх, тиле баш, болай минем бөтен тормышым бер үкенечле ахмаклык кына булачак бит!* Х.Камалов. *Сылу бит аны күңеле, уйлары белән генә түгел, бөтен тормышы, сулышы белән сагына.* М.Мәһдиев

7) Билгеле вакытта яки шартларда яшәү чоры. *Күчтавылдагы тормышын искә төшергәндә генә түгел, Янтыкта үткән бала чаклары турында сөйләгәндә дә, аның телендә гел атлар булды.* Н.Фәттах. *Гөлшәһидә үзенең Акъярдагы тормышын бик ук сөйләргә теләмәсә дә сөйләми булдыра алмады.* Г.Әпсәләмов

8) Гаилә, гаилә корып яшәү хәле. *Аның яшендәге кайбер кызлар тормышка чыгып, бала үстереп яталар.* Ф.Яруллин. *Ул аңлады: үз бәхете, үз рәхәте турында гына уйлаган ятим кыз ир белән хатынның тормышын җимереп ташлады, аны ялгыз калдырды.* Р.Габделхакова

9) Тереклек итү, тере булу, яшәү хәле. *Нефть – җирнең каны, куәте, нефть – җирдәге тормыш, тереклек.* А.Гыйләҗев. *Ераккарак күз салсаң, кая карама утлар балкый, торбалардан төтен чыга: шәһәр үз гаме белән яши, тормыш, тереклек итү бер генә минутка да тукталып тормый.* Р.Кәрами

10) *күч.* Җанлылык, хәрәкәт, ыгы-зыгы. *Галиянең йортында --- көнетөне шау-шулы тормыш, күңелле тормыш кайнаганы ерактан ук күренеп тора.* Н.Фәттах. *Казан хастаханәсенә килү --- аралашу офыгымны киңәйтеп җибәрде. Тормышым кайнап тора башлады.* Ф.Яруллин

◊ **Тормыш иптәше (юлдашы)** Гаиләдә ир яки хатын (бер-берсенә карата). *Исәнбаев – әйбәт егет, мине үзенә кияүгә чыгарга соравы да хак. Турылыклы тормыш иптәше һәм балаларыма кайгыртучан әти булачагына да ышанам.* С.Сабиров. **Тормышка чыгу** Иргә (кияүгә) чыгу. *– Әлбәттә, – диде ул, – тормышка чыгу, бүтән берәү белән тормышыңны бәйләү – йөрәк эше ул, ә йөрәккә кушып булмый, ул үзе аны теләргә тиеш.* Ә.Еники. **Тормыш кичерү** *к.* **тормыш итү**. *Шулай итеп, ике ыру кешеләре, кайгы, талау күрмәенчә, тыныч кына, тату гына тормыш кичергәннәр.* Н.Фәттах. *Адәм балалары бер-берсен өнәп бетермиләр, бер-берсенә түзеп тормыш кичерәләр.* Ф.Садриев. **Тормыш кору** Гаилә кору. *Тормыш корып җибәргән көннән башлап, Ләйлә белән Гайфулла арасында тиенкы мәхәббәт яшәп килде.* Ф.Яруллин. **Тормыш көтү** *к.* **тормыш итү**. *Сугыш вакытында фрау Эльзага авыл җирендәге кечкенә генә хуҗалыгы белән тормыш көтәргә туры килә.* А.Тимергалин. *Дөньяның рәтен белә Гайнуллин, ә яши белгән кешегә урман кирәк. Тормыш көткәндә дә, ял иткәндә дә.* М.Маликова. **Тормыш кушу** Яшәү, көн итү кирәклегеннән чыгып, авыр, кыен бер эш башкарырга мәҗбүр булу. *Тормыш кушкач, яңа төзелеп яткан Баракларга карап атладык.* Х.Җәгъфәр. *Көнгә ике юл – моны безгә әни түгел, тормыш куша. Ә без тормыш кушканны үтәргә өйрәнгән.* Ә.Гаффар. **Тормыштан артта калу** 1) Искергән карашлар белән яшәү. *Хәтимәнең әнә шундый борынгы алымнарыннан, сүзләреннән Кәрам, тавышын чыгармаска тырышып, авызын каплап көлеп утырды. --- Ул хатынының шулай тормыштан артта калуына хәзер генә төшенә башлады кебек.* Ш.Бикчурин; 2) Нинди дә булса яңалыклардан хәбәрсез калу. *– Монысын да минем ишеткәнем юк бит, Гөлшәһидә, – диде Вера Павловна, гаҗәпләнеп. – Бөтенләй тормыштан артта калып барам. Күптән кайтканмы соң?* Г.Әпсәләмов. *Үзе ул тормыштан артта калган кеше түгел, шактый гына укыган. Өстәвенә көндәлек матбугат белән дә кызыксынып бара.* Ф.Яруллин. **Тормыш юлдашы** *к.* **тормыш иптәше**. *Радмир – аның ире, ничә ел гомер иткән тормыш юлдашы.* Х.Мөдәррисова. **Тормыш юлы** Гомер. *Берүзе биш кешегә җитәрлек тормыш юлы үткән, дөньяның ачысын-төчесен җитәрлек татыган бу кеше белән сөйләшү – үзе бер гомер.* М.Хәсәнов. *Шул вакытта мин тормыш юлында очраган юньсез кешеләрне (алар инде миңа очраштыргалаган иде) уйлап алдым.* М.Мәһдиев

**ТОРМЫШ ИТҮ** *ф.* 1) Көн итү; яшәү. *Искелек, --- кешелекнең тормыш итү тәҗрибәсе, органик төстә яңалык белән берләшергә, яңалык такыр*

*җирдә түгел, шул тәҗрибә нигезе өстендә корылырга тиеш.* Р.Вәлиев. *Халык, бергәләшеп, яңа урында тормыш итә башлаган ---.* Ф.Гарипова

2) Гаиләкорып яши башлау, яшәү. *Шул көннән алып, Габәш белән Зарифат матур гына тормыш итә башлыйлар.* Р.Батулла. *Гөлшат белән аны сеңлесе таныштырды, әйбәт кыз, диде. Әйбәт дигәч, Миндар өйләнде. Тормыш итәр өчен әйбәт хатын кирәк икәнен ул белә иде.* Р.Габделхакова

**ТОРМЫ́Ш-КӨНКҮРЕШ** *җый. и.* Көн итү, яшәүнең иҗтимагый һәм матди яклары. *Илья Олегович кунагын үз каршысына --- утыртты да Иргалинең --- тормыш-көнкүреше турында сораша башлады.* М.Хәсәнов. *Авыл халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуга багышланган бу семинарга уналты районнан ике йөзләп кеше җыелды.* Ф.Садриев

**ТОРМЫШЛАНУ** *ф.* Иргә (кияүгә) чыгу яисә өйләнү, гаилә кору. *Тормышланган – төпләнгән.* Мәкаль. *Тормышлангач, Солтан бөтенләй үзгәрде: эчүен дә ташлады, сүгенүдән дә туктады.* Сөембикә

**ТОРМЫШЛЫ** *с.* Билгеле бер тормыш, яшәү рәвешенә ия булган. *Басу капкасы – утрак тормышлы татар авылларына гына хас корылма, басудагы игеннәрне, болыннарны малдан таптатмас өчен корылган чиннек, капка.* Р.Батулла. *Берәүләр аз йоклыйлар, күп табалар, һәрнәрсәне сак тотарга күнеккәннәр. Андыйлар җитеш тормышлы.* Ф.Садриев

**ТОРМЫ́ШЧА** *рәв. к.* **тормышчан 2.** *Мостафин, урыныннан торып, әрлебирле йөрергә тотынды. Әйе, диде ул үз-үзенә, кешеләр мәсьәләгә ничек гади карыйлар, тормышча карыйлар. Күрәсең, шулай карарга кирәктер дә, фәлсәфәдән баш кына тала, ә мәгънә чыкмый ---.* Ә.Еники. *--- ул сәхнәдә тормышча гадилек, чын садәлек булуны яраткан, һәртөрле фальшьны тиз сизгән, аны сәхнәдән мәрхәмәтсез рәвештә куган.* Н.Таждарова

**ТОРМЫШЧАН** *с.* **1.** Тормышта була торган, гадәти тормышка туры килгән. *Зөләйханың авылда ире һәм балалары, якыннары арасында, соңыннан руслар кулында яшәве чын тормышчан шартларда бара, аларда тормышчан дөреслек өстенлек итә.* А.Әхмәдуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Тормыштагыча, реаль итеп. *Менә бу хәл инде артистларның никадәр тормышчан итеп, бөтен шартын туры китереп уйнаулары хакында сөйли.* Р.Корбан. *Язучы әсәрендә 1917 елгы революциядән соң, яңа тормышта урын алу өчен, кайберәүләрнең иң якын һәм кадерле кешеләреннән дә баш тартырга мәҗбүр булуларын тормышчан сурәтли.* Р.Зарипова

**ТОРМЫШЧАНЛЫК** *и.* Тормышчан булу сыйфаты. *А.Гыйләҗев иҗатына кырыс реализм, тормышчанлык, психологик тирәнлек хас.* Х.Миңнегулов

**ТОРНА** *и. зоол.* 1) Торна кошлар семьялыгыннан озын сыйраклы, озын муенлы һәм озын томшыклы саз кошы. *Камышлы күлләрдә, елга буйларында бала чыгарырга җыенган аккошларның, кыр казларының һәм торналарның --- моңлы чыр-чуы, гүелдеге яңгырап торды.* Н.Фәттах. *Торыйк-торыйк торналар очып үтсә, Һәдия өчен үзе бер вакыйга.* Г.Якупова

2) *куч.* Озын аяклы яки озын буйлы, ябык кешегә карата әйтелә. *Әйт миңа теләсәң нинди сүз! Бәрәңге сабагы диген, борчак саламы диген, торна диген, колга диген – теләсәң ни әйт. Тамчы да ачуым килми.* И.Гази. *Озын аяклы, озын муенлы бу кешене авылда Торна Хәйри дип йөртәләр.* Г.Гыйльманов

◊ **Торна сыйрак** Озын аяклы кеше. *[Шакир бабай] башын аска салып торган Мухинга текәлеп: – Эх, торна сыйрак, торна сыйрак! Нәстә әйттем мин сиңа? – дип, катырак итеп әйтеп куйды.* Ә.Айдар. **Торна сыйраклы** *к.* **торна сыйрак**. *Бу кош борынлы, торна сыйраклы, һәрвакыт, кара күзлек киеп, күзен качырып йөрүче --- елгыр урысның чын исеме Дима иде ---.* А.Гыйләҗев. **Торна тәпи алып килү** Йөри, атлый башлау (балаларга карата). *Минем улыма, кара борыныма, торналар тәпи алып килде.* А.Гыйләҗев

**ТОРНАБАШ** *и бот.* Яранчалар семьялыгыннан чәчәкләре алсу шәмәхә яки куе кызыл төсле, орлык тартмачыгының формасы озын томшыклы торна яисә ләкләк башын хәтерләткән һәм аланнарда, коры болыннарда, яшелчә бакчаларында, ташландык җирләрдә, комлы ачык урыннарда үсә торган берьеллык чүп үләне; торна үләне; *русчасы:* **журавельник, аистник**

**ТОРНАЛЫ** *с.* Торналар яши торган. *Торналы саз*

**ТОРНАЛЫК** *и.* Озын аяклы һәм озын буйлы булу, озын буйлылык. *Иргали шушы буе аркасында җәфа чикте. --- Кызлар, гармун моңына сихерләнеп, аның торналыгын күрми башладылар.* И.Салахов

**ТОРНА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот. диал. к.* **торнабаш**

**ТОРОС** *и. саам* Төньяктагы елгакүлләрдә һәм диңгез-океаннарда бозлар үзара бәрелешүдән барлыкка килә торган зур боз өеме. *Бозлар, ярылып, кисәкләргә ватылалар, --- бер-берсе өстенә өеләләр һәм бозлар өеме – торослар барлыкка китерәләр.* Дөнья кисәкләре географиясе

**ТОРПЕ́ДА** *и. лат.* Сигара формасындагы үзйөрешле һәм үзидарәле снаряд, мина (диңгез сугышларында һәм тыныч хезмәттә дә кулланыла). *Немец торпедалары көймә яныннан бер-бер артлы ун мәртәбә сызгырып узып киттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Труба аша забойга торпеда төшерергә һәм колоннаның аскы өлешен шартлатырга карар кылынды.* Ш.Бикчурин

**ТОРПЕ́ДАЛАУ** *ф.* Торпеда белән шартлату. *Хәзер --- забойларны торпедалау киң таралды.* Нефть турында хикәяләр. *Корабльне торпедалауга әмер булмаганлыкта гаеплиләр аны.* Безнең гәҗит

**ТОРПЕ́ДАЧЫ** *и.* Торпеда аппаратында хезмәт итүче хәрби диңгезче, торпедист. *Ул Тын океан флотында хезмәт итә, торпедачы була, үрнәк матрос буларак, старшина дәрәҗәсенә күтәрелә.* Кызыл таң

**ТОРПЕДИСТ** *и. рус к.* **торпедачы**. *Менә Ломидзе һуштан язып егылды, корабль радисты хәлдән тайды, мотористлар, торпедистлар, электриклар аудылар.* Г.Әпсәләмов. *Син монда тор-*

*педист, артиллерист буларак кына сөйлисең, ә мин – шул эсминецның командиры.* М.Мәһдиев

**ТОРПЫЧА** *и. рус* Киндер сугу җайланмасының җеп урау өчен эшләнгән зур кәтүксыман детале. *Торпычага җеп урату*

**ТОРС** *и. ит.* 1) Кеше гәүдәсенең төп өлеше (башлыча баш һәм күкрәк). *Юан торс. Сыгылмалы торс*

2) Сынлы сәнгатьтә кеше сыны (башсыз һәм аяк-кулсыз). *Бронза торс. Таш торс*

**ТОРТ** *и. ит. кулин.* Төче камырдан май, йомырка, бал-шикәр, крем, җиләкҗимеш һ.б.ш. кушып пешерелә торган татлы ашамлык. *Ул бит гел безнең түрдә булды, мин ясаган тортларны ничек мактый-мактый ашый иде.* Х.Камалов. *Ирек аның кулына шоколад тоттырды. Өстәлгә түгәрәк тортны алып куйды. – Торт белән чәй эчәсеңме, кызым?* Ф.Садриев

**ТОРУ** *ф.* **1.** 1) Аяк өстендә билгеле бер урынга баскан хәлдә булу (аяклы җан ияләре тур.). *Кайтып киләм шулай, күрәм: безнең капка төбендә тарантаска җигелгән ат тора.* Г.Галиева. *Тукталдым. Борылып карасам – тротуарда ике кеше тора.* М.Мәһдиев

2) Аяк өстендәге халәткә килү, утырган, иелгән, чүгәләгән җирдән аякка басу, аягүрә калку. *Зифа, сикереп торып, колагын басып йөгерә.* М.Фәйзи. *Җәмилә Закировна, караватыннан торып, таягына таянып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөреп килде.* М.Маликова. *Хаммат, урыннан торып, Мөнирҗанга кулын гына биргән иде, соңрак түзмәде, кочаклап ук алды.* Н.Әхмәдиев

3) Тирә-яктагы предметларга яки кешеләргә һ.б.га нисбәтле билгеле бер торышта булу. *Секретарь кыз фикус гөле яфракларын ишеккә арты белән торган килеш чүпрәк белән сөртеп маташа.* Ф.Садриев. *Миңа шулай тез чәнчеп, сирәк-мирәк миңа яны белән торган шифоньерга эленгән түгәрәк көзгегә карап, ярты сәгать утырам инде.* Р.Кәрами

4) Гомумән тек, вертикаль халәттә булу (озын, озынча нәрсәләр тур.). *Тракторның борын төбендә генә геологлар утыртып киткән әлеге багана тора ---.* Г.Рәхим. *Ә почмакта иске һәм килбәтсез шкаф тора иде.* Г.Гыйльманов

5) Гадәттә баскан килеш берәр вазифа башкару. *Капка төбендә сакта торган милиционер Тансыкны, кызганып, әнисе янына кертеп җибәрә.* З.Зәйнуллин. *Эштә арыган-талган ул, аннары озаклап чиратта торган, авыр әйбер күтәреп кайткан.* М.Маликова

6) Нәрсә белән дә булса мәшгуль булу, берәр эш башкару. *Кәрәзле балны әллә ничек тылсымлап кисеп торганда, лапыр-лопыр атлап, күн итекләренә балчык төяп, ир-атлар кайтып керде.* А.Гыйләҗев. *Ат кузгалагы белән ат тизәгенә бераз көрпә салып изеп торганда, Сабир мөртәт салмыш баш белән сиздермичә килгән дә Зәйтүнәнең артыннан тоткан.* Р.Батулла

7) Янда, алда, каршыда булу. *Печән базарында, кибет алдында торучы кечерәк малайлар, аю күргән кебек, бу гаҗәп кыяфәтле адәмнең артыннан ияреп башладылар.* Ш.Мөхәммәдев. *Чиләкләп-чиләкләп, җирнең үзәгенә үткәреп яуган тоташ соры яңгыр стенасы көне буе күз алдында торды.* Х.Ширмән

8) Тукталган хәлдә булу. --- *станциядә урын юк, --- анда нинди дә булса башка поезд тора.* А.Алиш. *– Хәзер күрсәтәм мин аларга күрмәгәннәрен! – дип, машинасын бип-бип кычкыртып, Әнәс юлда торган пошига таба якынлашты.* А.Хәсәнов

9) Кайда да булса яшәү, гомер кичерү. *Без бер-беребезне бик аз белә идек, Дәүләкән кебек кечкенә җирдә торсак та, юньләп аралашканыбыз булмады.* Ә.Еники. *Юлга чыктык дию-ем шуннан: инде әйтүемчә, Абдулла абзыйлар күрше авылда торганлыктан, безгә аз дигәндә ике чакрым юл үтәргә кирәк иде.* Г.Галиев

10) Билгеле бер торакта урын алып яшәү. *Куянак исемле станциядән аз гына читтәрәк бер казармада тора идек.* Ш.Камал. *Буйдак очучылар барысы да бер үк тулай торакта торалар.* Р.Мөхәммәдиев

11) Гомумән яшәү, гомер кичерү. *Килен генә булып торыр өчен яшь чакларым үтте бит инде, үз балаларым җитеп килә, алар өчен торасым килә минем.* Ә.Еники. *– Озак тормас ахры, Мәрьям, Илмирыңны йөгерт Шәмгыя карчыкка. «Ясин» чыксын, – ди әни.* А.Хәйретдинова

12) Билгеле бер шартларда яшәү. *Синең якташларың ник Харбинда торып калды да, ни максаттан син берүзең Япониягә килдең?* В.Имамов. *Хатын бик теләп ахирәттә – ире янында торып калган.* Г.Гыйльманов

13) Гаилә корып яшәү; көн итү. *Бергә кушылу, бергә тора башлау турында алар бер генә мәртәбә дә сөйләшкәннәре юк иде. «Кил, Розочка, бергә тора башлыйк», – дию әллә ничек шыксыз, ятышсыз булып чыгар иде.* Г.Кутуй. *Безнең район җирендә, әйтик, врач кыз белән шофёр егетнең, өйләнешеп, матур гына торуларын --- күрергә була.* Ә.Еники

14) Уяну, уянып аякка басу. *Әниләре ачы таңнан торып эшкә китә.* М.Хәсәнов. *Иртәгесен йокыдан торгач, Фәгыйлә җиңги бер хәрәкәтсез яткан Заһрины күреп имәнеп китте ---.* М.Мәһдиев

15) Билгеле бер урынны биләү. *Үзәнлекнең бер кырыенда кечкенә авыл тора ---.* Р.Вәлиев. *Ур өстендә, урман кырыенда, Габделгали абзыйның ялгыз өе тора.* М.Галиев

16) Берәр пункттан билгеле бер ераклыкта булу. *Галия, волбашкарма йортыннан чыгып, волостьтан бер генә чакрым ераклыкта торган авылына табан атлады.* Һ.Такташ. *Саратовның татар гимназиясеннән Радищев урамы белән аскарак төшсәң, гимназиядән әллә ни ерак түгел Хәдичә әбинең өе тора.* В.Ильясов

17) Билгеле өлешләрдән оешкан, җыелган, төзелгән булу. *Халык ботка түгел, халык бик күп шәхесләрдән, кабатланмас берәүләрдән тора...* А.Гыйләҗев. *Коръән Кәрим төрле озынлыктагы 114 сүрәдән тора.* А.Тимергалин

18) Нәрсәдәндер гыйбарәт булу. *Тормыш гыйбрәтләрдән тора шул.* А.Хәсәнов. *Ничаклы ваемсызлык, үз-үзеңне гафу итмәслек мәгънәсезлек! Ләкин бу мәгънә нидән тора соң?* А.Вергазов

19) Берәр урында билгеле бер вакытка, билгеле бер хәлдә тукталып калу, тоткарлану. *Элекке көннәрдә Мансурның аерылышканнан соң да капка төбендә беркадәр басып торганлыгын белгәнгә, бүген бер минут тормый кайтып китәргә кушты.* Г.Әпсәләмов. *Әмма Иргали абый конторада әллә ни озак тормады, нindидер куанычлы хәбәр ишеткәндәй, күтәренке күңел белән борылып та кайтты.* М.Хәсәнов

20) Саклану, сакланган хәлдә булу. *Узган айда затлы күлмәк алган иде... Эшләмәгә иренә, ашамага көсәнә, дими чараң юк, үзенә һаман әйбер кирәк... Кулында акча тормый икән моның...* Р.Кәрами // Билгеле бер урында сакланып кала алу. *Шөпшә кәрәзендә бал тормаган, бал кортының кәрәзе акмаган.* А.Алиш

21) Билгеле бәягә сатылу, билгеле хакта, бәядә булу. *Хуш, мондый сәгать күпме тора, сезнеңчә?* А.Тимергалин. *Быел ике йөз илле сум торган сыерны киләсе елга биш йөзгә дә табып булмавы мөмкин...* В.Нуруллин

22) Алыштырыла алу, бәясендә булу, нәрсәгәдер бәрабәр булу. *Бер галим мең наданга тора.* Мәкаль. *Бал бик зәһәр иде, чынлап та коньякка торырлыгы бар ахрысы.* Х.Камалов. *Бер матур җөмләсез роман язганчы, бер матур романга торырлык җөмлә язуың хәерлерәк.* Р.Миңнуллин

23) Билгеле бер хәлдә, халәттә булу. *Ә эш болай тора иде: гыйльми совет җыелырга өч көн кала гына кемдер, әгәр Марат Вәлиевич уңышлы якласа, аны профессор Хәсбиев урынына тәкъдим итәләр икән, дип хәбәр тараткан.* М.Мәһдиев. – *Мәсьәлә менә болай тора, – дип башлады ул, идарәгә кереп утыргач.* В.Нуруллин

24) Билгеле бер хәлдә, халәттә вакыт үткәрү. *Тынычлыкта торамын, хуш күңелмен.* Дәрдемәнд. *Көз җиткәч --- каеннар яфрак коялар, --- ялангач ботакларын салындырып, моңсулыкта торалар.* Ш.Хөсәенов

25) Чиратлы процедураны үтү. *Комиссия торам да яңадан сугышка китәм.* Ш.Маннур

26) *күч.* Билгеле бер сыйфатта, фикердә, караштa булу. --- *икенчеләре --- җинаятьчеләрне бик каты хөкемгә тартырга, хәтта авылдан сөрергә кирәк, дигән фикердә тордылар.* Х.Ибраһим. *Муса Җәлил хакында истәлекләремне искәртүне үтенгәч, аңа карата нинди яхшы караштa торуымнан башлап китеп, Һади Такташка күчкәнмен ---.* Ф.Яхин

27) *күч.* Кемгә дә булса карата билгеле фикереңне, эчке сыйфатыңны, мөнәсәбәтеңне белдерү, чагылдыру. *Без – бу урында яңа кешеләр, барысы да безгә сынап карыйлар, шулай булгач, күршеләргә ачыграк, йомшаграк тору безнең үзебез өчен кирәк ләбаса!* Ә.Еники. *Ни дисәң дә, галим халкы тормыштан еракта тора, аңардан аерым яши шул.* Ф.Яхин

28) *күч.* Билгеле бер ялгыш фикердә, уйда булу. *Мин аны Йосыф абзый дип торам, ә ул Сәҗидә мәлгунь икән!* М.Галәү. *Асылгәрәй картны кайтаралар дип торганда, Маһинур абыстайны алырга килүләре барысын да шашындырды, куркытты.* Ф.Бәйрәмова

29) *күч.* Юклык формасында (*дип тормау*) нәрсәгә дә булса яисә нindидер шартларга карамау, игътибар итмәү; теге яки бу сәбәпкә карап, берәр эшне үтәүдән тукталып калмау, куйган максаттан чигенмәү. *Директор өнәп бетерми дип тормадылар – кызлар яраттылар әле үзен.* М.Мәһдиев. *Бабай, кыз аңлыймы, юкмы дип тормады, чип-чиста татарча эндәште.* А.Әхмәтгалиева

30) *күч.* Билгеле дәрәҗәдә, позициядә булу; нәрсәгә дә булса билгеле мөнәсәбәттә булу. *Мин эш-белем ягыннан алдынгы ирләр белән бер югарылыкта торган --- татар --- хатын-кызларын беләм.* Г.Кутуй. *Ә милләт язмышы кебек иҗтимагый мәсьәләләргә әлегә авторлар битараф, алар игътибардан читтә тора.* А.Әхмәдуллин

31) *күч.* Саналу, исәпләнү. *1917 ел түнтәрелешенә кадәр төрки халыкларның мәдәният һәм мәгърифәт Мәккәсе булып Казан шәһәре торды.* Т.Галиуллин

32) *күч.* Кем яки нәрсә өчен тырышу, көрәшү, шуны хуплау, яклау, шул яклы булу. *Ничек үлим, Берләр – меңнәр өчен, Меңнәр берләр өчен торганда?!* Һ.Такташ. *Бармы бездә милләт өчен торган җитәкче?*

33) *күч.* Киләчәктә үтәлергә, башкарылырга тиешле булу. --- *бәрәңге алу башланды гына, алда чөгендер тора, тыгызга туры киләчәк.* М.Маликова. *Алда госэкзаменнар тора бит, диплом язасы бар.* А.Хәсәнов

34) *күч.* Нинди дә булса мәсьәлә берәр нәрсәгә, шәхескә яки объектның берәр сыйфатына бәйле булу. – *Алдавын алдар идем дә, алдар капчыгым өйдә калган, мин килгәнче бу каенны аудармыйча терәп торсаң, атың белән барып алып килер идем, – дигән Алдар. – Бар, бар, – дигән бай, – каеннан эш тормас!* Әкият. *Самолёт эчендә үк һәлак булмасаң, парашюттан файдаланып исән калырга тырышу үзеңнән тора.* Ф.Хуҗин

35) *күч.* **тормау** *юкл. форм.* Төп мәсьәләне хәл итү хакына кыенлыкларны, киртәләрне һ.б.ш.ны җиңеп чыгарга әзер булу. *Вәгаләйкемәссәлам, Әхмәтфаиз агай, киләсе җомгада бер әйләнә алмассыңмы? Минем Зәйнәгытдингә биш яшь тулып килә бит. Хакыннан тормас идек...* М.Мәһдиев. – *Бәясеннән тормам, яса миңа да шундый тәрәзә йөзлекләре, – дип мөрәҗәгать итте җитәкче.* Р.Мөхәммәдиев

36) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса тугрылыклы булу, чигенмәү, тайпылмау. *Әллә берәрсе каршы алырга вәгъдә итеп тә сүзендә тормадымы?* М.Маликова. *Бер елдан, әйткән вәгъдәсендә торып, кайтып та төште.* З.Мурсиев

37) *күч. гади с.* Нәрсәне дә булса эшләүнең кирәге, әһәмияте, дәрәҗәсе булу. *Бер соратуга килми, ике соратуга тормый.* Әйтем. *Дошман булса – булсын икән булырдае, Сугышканда дәрәҗәңә торырдае.* Н.Исәнбәт

**2.** *ярд. ф.* 1) Эш яки хәлнең даими булып торуын, системалы кабатлануын белдерә. *Бәлки, тагын берәр кат эшләргә туры килер әле. Өр-яңа уйлар, фикерләр килеп тора.* Ф.Яруллин

2) Төп фигыльдә белдерелгән эш-хәрәкәтнең яисә халәтнең өзлексез дәвам итүен, бертуктаусыз булуын белдерә. *Парашаны тәүлеккә бер мәртәбә*

*генә чыгаралар икән, сасы сыекча мичкәдән ташып, идәнгә агып тора.* Р.Мостафин. *Шуның өстенә көне-төне берничә атом реакторы эшләп тора, көне-төне тирә-якка радиация тарала.* Ф.Бәйрәмова

3) Эшнең билгеле бер моментка, эш-гамәлгә, вакыйгага кадәр башкарылуын белдерә. *Ә аңарчы әле бер атна вакыт бар: әйбәтләп әзерләнә торыгыз!* В.Нуруллин. *– Пока Каенсарда пионер лагеренда эшли торырсың, сентябрьдә күз күрер, – диде ул.* Г.Әдһәм

4) Төп фигыльдән соң *да/дә, та/тә* кисәкчәләре белән килеп, нәрсәнең дә булса озакка сузылуыннан ризасызлыкны, пошынуны белдерә. *– Җепнең монысы, минемчә, бик үк әйбәт булмады, чуала да тора, көчкә рәткә китердем, – диде мулла хатынына.* М.Галәү. *Фаяз, үзенең болай конкрет сөйләп, эшне чуалтканын сизгәндәй булды. Бераз шомартырга, юмор кушарга кирәк булган бит. Әй бу турыдан яру, нәләт, аңа комачау итә дә тора, хәерсез.* Ф.Садриев

5) Аналитик фигыльләр составында кабатлаулы үткән заман формасын көчәйтеп килә. *Кызыбрак киткән чакларында Шаһи карт киявенә тагын да катырак сүзләр әйткәли торган булган.* Г.Әпсәләмов. *Гаиләдә ата-ананың музыкага битараф булмавы да роль уйнагандыр, бәлки. Аның әтисе Шәриф агай «русский строй»да яхшы гына уйный торган булган, әнисе Мәфрүзә дә җырларга яраткан.* М.Макаров

6) Берәр эш яки шөгыльне башларга әзерләнгән яки ниятләнгән хәлдә булу. *Кызын беләсез, шәһәрдә кызлар мәктәбендә укыган. Көймәләргә утырырга торганда гына көчле давыл куба.* М.Хәбибуллин. *Мәкаләне язып җибәргәнгә дүрт көн үткәч, кичке ашка барырга торганда гына, рота командиры капитан Мачков мине үз янына кәнсәләргә чакырып алды.* В.Нуруллин

7) Юклык формасында катгый инкяр итүне белдерә. *Уйлап та торма – бар да кер! Сөйләп тә торма: барыбер тыңламыйм!*

8) Төп фигыльдә белдерелгән эш-хәрәкәтнең яки сыйфат-халәтнең бера ра яисә вакытлыча булуын, дәвам итүен белдерә. *Ә таң аткач, --- [утлар] кайдадыр куышларда посып, көнозын яшеренеп торалар да, төн булгач, яңадан йөгереп килеп чыгалар ---.* Г.Әпсәләмов. *Ишан авырып тора икән.* З.Зәйнуллин

9) Билгеле бер үзенчәлекле халәттә булуны ассызыклый. *Ләкин моның уңышсыз очланасын Тамара алдан ук белеп торды.* М.Мәһдиев. *Ул бит ничек бетеренүемне күреп торды.* М.Кәбиров

10) Берәр үзгәрешсез, даими сыйфатны белдерә. *Тәрәзә төбендә, Мотаһирның үз өендәге кебек кызыл чәчәкле кына гөле яки бүрек хәтле яран түгел, ниндидер ят гөл үсеп утыра. Ят булса да, ул барыбер өй эчен ямьләп тора иде.* Р.Кәрами. *Озынча йөзен тукмак борыны бозып тора...* М.Маликова

11) Эш-хәрәкәтнең нәкъ хәзерге моментта башкарылуын яки билгеле бер үзгәрештә булуын белдерә. *Без бүген Солтангәрәй байлар белән юлга чыгарга ниятләп торабыз.* Т.Гыйззәт. *Минем күңелдә бер уй туып тора бит әле.* Г.Ахунов

12) Төп фигыльдә белдерелгән гамәлнең кирәксез, әһәмиятсез, кыска вакытлы булуын белдерә. *Ачуым килеп китте, нигә әле мин бу кешедән куркып торам, дигән уй белән, кыза төшеп, туп-туры үзенә әйттем: – Мин партия боерыгын яклыйм, беләсегез килсә.* Ә.Еники. *Әле яңа гына дөнья күргән япь-яшь агач булгангамы, авырып та тормады диярлек, әрсезләнеп, бик тиз тамыр җәйде.* М.Шабай

13) Берәр эш-гамәлгә әзер булу, шуны башкару алдында булу. *Заһид әле, армиядән кайткач, эшкә кермәгән, барып сорар җире юк, Фәнияр берничә айдан китәргә тора.* Ф.Яруллин. *Бүген-иртәгә көзге чәчү башланырга тора бит!* В.Нуруллин

14) Эш-хәрәкәтнең ихтималлыгын белдерә («мөгаен» мәгънәсендә килә). *Көтү чираты да якынлаша торгандыр инде.* М.Мәһдиев. *--- балалар күңеленә юл табу, аңа үтеп керә алу бәхете бик сирәкләргә генә тия торгандыр.* Р.Миңнуллин

15) Билгеле бер караштa, фикердә булу. *Мин Казанга кайткач та, мөгаен, барып чыгарбыз дип торам.* Х.Туфан. *Романны, Алла боерса, Ходай насыйп итсә, Аллаһы Тәгалә илһам бирсә, тагын бераз көч бирсә, озакка сузмый гына төгәлләрмен дип торам.* Р.Миңнуллин

16) Төп фигыльгә ялганып, билгеле бер эш-хәрәкәтнең бик озак дәвам итүен белдерә. *Дөрестерме-түгелдерме, берзаман эштән кайтканда йоклап киткән бу. Әй бара, әй бара икән, бара торгач, районның икенче башына барып чыккан, имеш.* Ф.Яруллин. *Коръән тәрҗемәләрен һәм тәфсирләрен каткат укый торгач, чыннан да аның могҗиза икәненә ышанасың.* Р.Батулла

**3.** *бәйл. функ.* 1) Кире бәйләнешле җөмләләрдә бәйлек «шуңа карамастан» мәгънәсен белдерә. *Бу җүләр дә инде, минем шикелле, бүләккә кызыгып, кызның начар икәнен белә торып, бергәләшеп мактый.* Г.Камал. *Гайрәтең ташып торган ир була торып, баш өстеңдә түбәң, теш араңа кыстырырлык бер кабым икмәгең булмасын инде, ыстырам!* М.Хәсәнов

2) Юклык формасында килеп, берәр нәрсәгә карата «булмастан (булдырмастан) элек, эшләмәстән элек» дигән мәгънәне белдерә. *Яңа чәчкечләр кайтмыйча торып, тагын бер-ике агрегат җибәрмичә торып, берни барып чыкмаячак.* Н.Фәттах. *Без аңардан үрнәк алабыз: оккупантларны бетерми торып, ир-ат халкы белән мөнәсәбәткә кермәскә ныклы сүз куештык, һәм без үз сүзебездә торачакбыз!* Х.Камалов

◊ **Тора тор** *к.* **торып тор**. *Минһаҗетдин алманы алыйм дигәндә генә, йомыркачы: – Тукта, тора тор әле син! – дип, алманы Миңсылуга бирде.* К.Тинчурин. *Ул --- ашыгып баскычка менде. – Япмале, кызым, тора тор, – диде ул, Мәрьямгә кычкырып.* Н.Фәттах. **Торган саен** Вакыт үтү бәрабәренә артып, зураеп, көчәеп, көчәя барып. *Хәленең дә торган саен авырайганнан-авырая баруын тойды.* М.Хәсәнов. *– Егылып төшсәң, дөньяда убырлы карчык кимер, – дидем мин, басманы торган саен ныграк тирбәтеп.* Ф.Яруллин. *Авыл җирендә яшәүче һәр кешенең бердәнбер булуына торган саен күбрәк инана барам.* З.Хәлиуллина. **Торып**

**калу** Гадәти хәлендә кала бирү. *Алынмаган унбиш сутый бәрәңгесе бүген дә шулай түтәлендә торып калды.* В.Нуруллин. **Торып тор** Ашыкма, кабаланма, азрак көт. *[Марат:] Сәрвиназ-каракаш! Чак кына торып тор, сүземне тыңла...* А.Гыйләҗев. *Фәләх конфет каптырмакчы булган иде, Гасимә: – Торып тор әле, чатнауны басмады бу, – дип, тагын бер рюмка эчте.* В.Нуруллин. **Торып тору** 1) Үз нәүбәтен яки берәр эш беткәнен һ.б.ны бераз көтү, кичектерү. *[Әхмәт:] Тукта әле, ул кадәр ашыкма. Теге эчкәне бераз урынына урнашсын. [Шөҗаг:] Зарар юк, зарар юк, алайса, бераз торып торсын.* Г.Камал. *Кияү егет тә, башкода да булдым, кыз да урлаштым. Шулай бервакытны... Ярый, анысы хәзергә торып торсын, соңыннан сөйләрмен.* Г.Бәширов. *Тимербулатның башы әйләнеп киткән кебек булды. Тукта, нәрсә диде әле бу хатын, Сигнал бездә торып торсын, дидеме.* Ф.Бәйрәмова; 2) Игътибардан читтә булу. *Санаторий-профилакторийлары торып торсын әле! Бишәлектәге кебек саф һава тагын кайда бар?* С.Шәрипов. **Торып-торып төрҗәгун** 1) Бер үк нәрсәне кат-кат сөйләү, инде хәл ителгән мәсьәләне яңадан күтәрү турында. *[Илдар:] Аннан инде, син торган хуҗаның капка төбенә утырып, таң атканны да сизми кала торган идек... [Дания:] Тукта әле, торып-торып төрҗәгун, дигән шикелле, ни өчен син аларны хәзер миңа сөйләргә булдың?* Т.Гыйззәт. *Кәшифә --- өзелгән сүзне ялгап, Мөкәррәмәгә киңәштабыш итәргә дә җитеште: – Торып-торып төрҗәгун, ди, Өммия сиңа көндәш түгел, үскәнем, ул налуг Газраилен эләктерде инде, – диде.* М.Әмирханов; 2) Тора торгач, көтмәгәндә, урынсыз бер сүз әйтеп кую турында

**Тора башлау** Торырга ниятләү, тору хәрәкәте ясау, кузгалу. *Авылда фатир таба алмагач, Ханәфи шул өйдә тора башлады.* В.Нуруллин. *– Каяле, кая, кызымны карыйм әле, – дип, Зәйтүнә кулын сузган гына иде, беренче өстәлдә ятучы Саимә, әллә саташып, әллә авыртуы басыла төшеп, урыныннан тора башлады.* Г.Галиева

**Тора бирү** Бернигә дә карамыйча торуны дәвам итү. *Гөлниса баскан урынында каткан кебек тора бирде.* М.Хуҗин. *Искәндәрнең стаканы тулы килеш тора бирде.* Р.Вәлиев

**Торып алу** Кыска вакыт эчендә, бераз тору. *Солтан К.Насыйри урамнары чатындагы (6/12), аннары Миславский урамындагы (3) йортларда торып ала ---.* Р.Әмирхан. *Шагыйрьнең авылга кайтып, Өчиледә торып алуы вакытын мин үзем дә «Тукайдан хатлар» әсәренә нигез итеп алган идем.* Татарстан яшьләре

**Торып карау** Тору мөмкинлеген сынау. *Безнең авыл малайларыннан кем торып караган мондый бай өйдә?* Г.Бәширов. *Торып кара миннән башка гына, белерсең ир кадерен.* Н.Хәсәнов

**Торып килү** Акрынлап тору; тора башлау. *Пәрдәсе тартылмаган тәрәзәдән Нагорный бистәсендә торып килгән кояшның нурлары үтеп керде.* Р.Рахман. *Торып килгән җиреннән кулы таеп, Сәрия башы белән тимер караватчитенә бәрелде.* Т.Гарипова

**ТОРФ** *и. нем.* 1) Сазлыклы җирләрнең өске өлешендәге череп бетмәгән үсемлек калдыкларыннан барлыкка килгән, ягулык, ашлама буларак яки төрле техник максатларда кулланыла торган масса. *Каян торфын таптылар да, болынны киптереп, сөреп ташлау кайсы тилесенең башына килде икән?* Ф.Бәйрәмова. *Янган торфны сүндереп тә буладыр, ә минә утлы сүзнең көйгән эзе беркайчан бетми, юкка чыкмый.* М.Маликова

2) *сөйл.* Шул массаны чыгару эше. *Сер шул: торфка җибәрергә колхоздан кызлар сорыйлар.* Ф.Яруллин

**ТО́РФКИСКЕЧ** *и. тех.* Әзер торф массасыннан брикетлар ясый торган машина

**ТО́РФЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **торфлау**. *Торфланган җир*

2) Торфка, торфлыкка әверелү. *Кобау дип торфлана торган күлгә әйтәләр*

**Торфлана башлау** Торфлану билгеләре күренү

**Торфланып бетү** Тулысынча, бөтенләй торфлану

**ТО́РФЛАУ** *ф.* Туфракны торф белән ашлау, торф кертү. *Мең гектар җирне торфлау*

**Торфлап бетерү** Ахыргача, беткәнче торфлау. *Тирә-яктагы басуларны торфлап бетерделәр*

**Торфлап карау** Сынау максаты белән торфлау

**Торфлап кую** Алдан ук торфлау. *Торфлап куйган урынга яшелчәләр утырту*

**Торфлап тору** Әледән-әле яки хәзер, әле торфлау

**Торфлый башлау** Торфларга керешү. *Урман буендагы басуларны торфлый башладылар*

**ТО́РФЛЫ** *с.* 1) Торф катнашкан, составында торф булган. *Торфлы сазлыкларда халык күп яшәми, һәм шуңа күрә монда азмы-күпме таныш кешеләр дә бер-берсе белән йөрешергә тырышалар.* Р.Вәлиев. *Эсселек һәм торфлы газдан Мәскәүдә көн саен 700 ләп кеше үлә.* Л.Харрасова. *Бәрәңге ---комлы һәм торфлы җиңел туфракларда яхшы үсә.* Агулы үсемлекләр

2) Үзенә торф кертелгән. *Торфлы туфрак*

**ТО́РФЛЫК** *и.* Торф күп булган яки аны чыгара торган урын; торф ятмасы, торфлы сазлык. *Бара торгач, Питрәч юлы өстендәге торфлыкка килеп чыктык.* К.Кәримов. *Шалкан, торма һәм гәрәнкә --- киптерелгән торфлыкларда барыннан да яхшы үсә.* Йорт эшләре. *Табылдыклар борынгы корылмага һава керүне тоткарлаган торфлык ярдәмендә яхшы сакланган.* Мирас

**ТО́РФ МҮГЕ** *и. биол.* Сфагнумчалар семьялыгыннан сабагы куе тармаклы, вак кына куе яфракчыклар белән капланган, торфлы сазлыкларда торф составын тәшкил итә торган сыек яшел, сары, коңгырт яки кызгылт төстәге сабак-яфрак үсемлек; *русчасы*: **сфагнум**. *Торф мүгенең анатомик һәм гигроскопик үзлекләре йөзләрчә еллар буе рәттән аны бәйләвеч материал буларак файдаланырга мөмкинлек бирде.* Урман аптекасы

**ТО́РФСУЫРГЫЧ** *и. тех.* Торфны гидравлик юл белән күтәртә, чыгара торган машина

**ТО́РФ-ЧЕРЕМӘ** *с. а.х.* Торф һәм черемә катнашмасыннан торган яки шуннан ясалган. *Торф-черемә чүлмәкләр*

**ТО́РФЧЫ** *и.* Торф катламнарын өйрәнүче белгеч яки торф чыгаручы эшче. *Торфчылар кайткан. Сугыш вакыты. Фронттагы кебек тылда да хәлләр киеренке.* Т.Биктимерова. *Сугыш вакытында торфчы кызлар фидакярлек күрсәттеләр.* Казан утлары

**ТОРШЕР** *и. фр.* Идәнгә бастырып кую өчен озын терәге булган лампа. *Тагын беркадәр вакыттан ул йокы бүлмәсенә керде, торшер яндырды ---.* Р.Кәрами. *Торшердагы утны кабызып, айларны, елларны яңадан актара башлыйм.* М.Галиев. *Алар янында яшел абажурлы торшер гына яна.* М.Маликова

**ТОРШОН** *и. фр.* 1) Бик сирәк итеп (гадәттә шакмаклап) тукылган киҗемамык тукыма

2) Үзенең шакмаклы һәм кытыршы өслеге белән шул тукыманы хәтерләткән кәгазь

**ТОРЫЙК** *иярт. к.* **торыйк-торыйк**

**ТОРЫ́ЙК-ТОРЫЙК** *иярт.* Торна кычкырган тавышны белдерә. *Торыйк-торыйк торна тавыш бирсә, Нәкышь чиккән җебем чуала.* Җыр. *Кычкырдылар: «Торыйк-торыйк, Сезнең белән дуслар булыйк, тату яшик, бергә торыйк!»* Г.Афзал. – *Безнең якларга яңа язлар китерегез! – Ярар, – дигән торналар. – Торыйк-торыйк, юлда булыйк. – Шулай дип әйткәннәр дә күккә күтәрелә башлаганнар.* Ф.Яруллин

**ТОРЫ́ЙЛЛЫК** *иярт. к.* **торыйк-торыйк**. *Торыйллык дип соңгы сәламен биргәч кенә, [кошыбызның] гапгади бер торна икәнлегенә төшендек.* А.Гыйләҗев

**ТОРЫК** *и.* 1) Читән яки киртәнең ике казык арасындагы бүлеме, буе. *Бары тик югары очтагы кибет янында берничә торык туры тыкрык сузыла.* Х.Камалов. *Шыр ачык урыс капка аша ишегалдына карагач, профсоюз Габделхәмит имәнеп китте: --- ак мунча урынында кисәү өеме пыскып утыра, ишегалды ермачланган, урыс капканың бер баганасы төптән кырт өзелгән, бер торык койма ауган ---.* М.Мәһдиев. *Араталары белән бергә бер торык койманы алдырта, җигүле ат шул урыннан ишегалдына кертелә.* Т.Нәҗмиев

2) Ике терәк яки субай арасы. *Лапас торыгына яңа кайчы утыртырга кирәк.* Ф.Хөсни. *--- басманың бөтен такталарын да алып ташлап тора алмады Миңнулла. Шулай да аргы як ярдагы бер торыгын алып ташларга өлгерде.* В.Нуруллин. *Тагын берничә минут һәм... боз-су ташкынына түзә алмыйча, күпер торыклары шартлап сына, ава башлый.* Ф.Әмәк

3) Аяк, бот. *[Поши баласы] колынга охшап бара: сыйраклары нечкә, торыгы озын.* Г.Әпсәләмов. *Ат озын торыкларын еш-еш хәрәкәтләндереп юырта башлый.* А.Расих. *Мәҗит исә, килеп ябышуы була, әле бер яклап, әле икенче кырыйдан озын торыгын китереп тыга, чалып аударырга тырыша малайларны.* Ф.Сафин

**ТОРЫКЛЫ** *с.* 1) Билгеле сандагы яки сыйфаттагы торыгы (*2 мәгъ.*) булган. *Корыч конструкцияләр сәнәгый биналарда, озын торыклы җәмәгать биналарын япканда, күпер һәм эстакадаларда, каланча һәм мачталарда, --- һәм башкаларда кулланыла.* Төзү материаллары. *Бүген ике торыклы (пролёт) күпер өчен субайлар сугыла.* Шәһри Казан

2) Аяклы, ботлы. *Ыргылып чабып китәргә әзер торган ак бәкәлле, озын торыклы ярсу кара айгырның дилбегәсен нык итеп тоткан килеш кучерда утырган егеткә Гали абзый --- игътибарлы караш ташлады.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин ерак китә алмадылар, каршыларында могҗиза күренде: анда – сукмакта – гаҗәеп картина булып, җыйнак гәүдәле, озын торыклы җәнлек басып тора.* М.Рәфыйков. *Шулчак, бакча рәшәткәләренә сырышып диярлек, озын торыклы, салпы колаклы ала эт йөгереп үтте.* Ф.Шәфигуллин

3) Билгеле терәге, баганасы булган. *Бакча ягында, аллы-гөлле мәк чәчкәләре арасында, бер-ике умарта янында, бер башында авыр таш, тимер тәгәрмәч бәйләнгән сиртмәсен, һавада асылынып калган буш бидерәсен тотып, озын торыклы кое баганасы калкып утыра.* Н.Фәттах. *70–80 яшьләр чамасындагы бер карт, мәсәлән, ниндидер озын торыклы велосипед өстендә урамның урта бер җирендә әйләнеп йөри.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Билгеле бер җирлеге, нигезе булган. *Үземне халыкның дусты, аның чын баласы санап һәм аңарга ничек тә булса яхшылык эшләргә теләгәнлектән [китапларымны] яздым. Нык торыклы булып чыкканнармы алар, чирләшкәләрме?* Ф.Хөсни

**ТОРЫЛДА́У** *ф.* «Торыйк-торыйк» яки «тор-тор» дигән авазлар чыгару (торна, ләкләк ише кошлар тур.)

**Торылдап алу** Берара торылдау

**Торылдап кую** Бер тапкыр торылдау. *Йөз чыпчык чырылдавыннан бер торнаның торылдап куюы артык.* Мәкаль

**Торылдап тору** Даими яки әледәнәле торылдау

**Торылдый башлау** Торылдарга тотыну

**ТОРЫМ** I *и. диал. к.* **торымбаш**

**ТОРЫМ** II *и. диал.* Тормыш, яшәү. *Яхшыга торым юк, начарга үлем юк.* Мәкаль. *Авылларда торым бетте.* Татарстан яшьләре

**ТОРЫМБАШ** *и.* 1) *диал.* Кисәү, янып бетмәгән утын яркасы, кисәү башы; янгыннан калган агач кисәге; су сибеп сүндерелгән утын. *Ялгыз торымбаш ялынсаң да янмас.* Мәкаль. *Кулларына утлы торымбашлар тоткан ике кеше ике якта тора.* Н.Фәттах. *Күрәсең, алар эштә чакны күтеп кенә очырылган кызыл әтәч йорттан торымбашларны гына калдырды.* А.Хәлим

2) *биол.* Янган шырпыга охшаш ашлык гөмбәчеге, арыш анасы

**ТОРЫМЛЫ** *с. сөйл.* Дәвамлы, кирәгеннән артык дәвам иткән. *Торымлы кунак. Торымлы утырыш*

**ТОРЫМНА́Н-ТОРЫМГА** *рәв. сөйл.* 1) Әледән-әле, вакыт-вакыт, еш кына. *Вәдүт Юнусович торымнан-торымга күкрәкне каты иттереп кыса.* З.Хәким. *Гаиләдә торымнан-торымга була торган ызгыш-талашларның сәбәбе кайчакта онытыла, чөнки ирхатын еш кына бөтенләй сәбәпсез*

*ызгышалар, ә талашу урыны күңелгә уелып кала.* А.Гыйләҗев. *Кешелек дөньясында мәңгелек бер парадокс хөкем сөрә: дөньяга бәхетле булырга --- килдем, дигән уй-хыялы бичара адәм баласын гел тынгысызлыкта тота --- һәм торымнан-торымга хәсрәт дәрьясына тотып ата ---.* Сөембикә

2) Бербуй, буеннан-буена, тоташ. *Аннан, аларның дисәтинәләре дә, безнең авыл байларыныкы кебек, торымнан-торымга түгел.* Т.Гыйззәт

3) Урыны-урыны белән. *Баткак җир өстенә агач түшәлгән тар гына юлдан ике автомашина кара-каршы узарлык түгел. Андый урыннар торымнан-торымга гына.* Ш.Маннур. *Балага, кайда торымнан-торымга бер арбадан икенчесенә, ә кайда исә тәпи-тәпи дә үтәсе булыр ахрысы...* Р.Гаязетдин

**ТОРЫМСЫЗ** *с. сөйл.* 1) Кыска гомерле, аз яшәүчән. *Торымсыз бала*

2) Тиз китә торган. *Торымсыз кунак кызы*

**ТОРЫМТАЙ** *и. монг. зоол.* 1) Лачыннар семьялыгыннан вак кимерүчеләр һәм бөҗәкләр белән туклана, бик җитез оча торган кечкенә ерткыч кош; *русчасы:* **пустельга**. *Куй көтүем суга төште, Сөләйман аксак куа төште, Карагай калпак каплый төште, Торымтай эзли төште.* Табышмак. *Кош тырнагы тимәгән, Күк лачын да типмәгән, Ул кош булыр торымтай.* Н.Исәнбәт

2) *күч. мыск.* Озын аяклы кеше

**ТОРЫН** *и.* Оныкның баласы. *Бусы Миңлебай картның олы торыны тол Таҗи иде.* М.Галәү. *Ханнар һәм югары катламда торган төрле кланнарның балалары, оныклары һәм торыннары арту сәбәпле дә, олыслар географик яктан вакланыш кичергән.* Н.Гариф. *Баксаң, торын – ул оныкның баласы икән.* Р.Батулла

**ТОРЫП** *кис.* Эш яки шөгыльнең бик кызу, кискен, шәп эшләнү, башкарылу төсмерен бирә. *Үгез баштарак әллә күрмәде, әллә күреп тә аңышмыйчарак торды, каршысында теге ир маймыл кебек сикеренеп үрти башлаган иде, борын тишекләрен киереп, үкереп торып җибәрде.* Н.Әхмәдиев. *Әмма аның сүзләре Мирсәеткә төбәлгән иде: – Сугып торып җибәрермен... Очып барып төшәрсең.* Р.Мөхәммәдиев

**ТОРЫ́П-ТОРЫП** *рәв.* 1) Әледәнәле, вакыт-вакыт. *Нәҗип белән Наилә, бугазлары кычытуны баса алмыйча, торып-торып сөт эчеп килделәр.* А.Гыйләҗев. *Кешеләр бу якка торып-торып карый башладылар.* Г.Гыйльманов

2) Вакыт узган саен көчлерәк булып. *Гасыйм Сәлахович торып-торып аптырый: әллә бу хатыннар кырык биштән узгач психически үзгәрә башлыйлар микән?* Ә.Еники. *Дөньясы тәмам түгәрәкләнгән кеше сыман диваналанып утыруын гына күрче син! Торып-торып хәйран калырсың, билләһи!* М.Хәсәнов

**ТОРЫПША** *и. рус* 1) Зур, киң, калын киндер яки брезент җәймә. *Ул, торыпшаны таратып, арба астында куыш сыман нәрсә ясады.* М.Хәсәнов. *Бераз читтәрәк, агачлар арасында яисә күтәртелгән тәртәләргә ябылган торыпша күләгәсендә аерым гаиләләр, самавырлар куеп, чәй эчеп утырган ---.* М.Бакиров

2) *диал.* Юлда йөргәндә, атка азык (гадәттә солы) салып, атның башына кидерелә торган махсус капчык; торба. *Атларга да солылы торыпшалар кидереп куйдым.* М.Хәсәнов. *[Без], торыпшаларга солы тутырып, атларга бирдек.* Ә.Айдар

3) Тар тирән тубал. *[Сәхнәгә] башына кабык торыпша шикелле кара цилиндр кигән --- бер кеше елмаеп килеп чыкты.* И.Гази

**ТОРЫШ** *и.* 1) Гәүдәнең, аяк-кулларның теге яки бу рәвештә тотылышы, басып яки утырып тору рәвеше; поза. *Егетнең йөз кыяфәте һәм сынын тотышы, портрет күрсәтүенә караганда, бик сөйкемле иделәр: ачык маңгай, --- озын мыек һәм күкрәген киерелдеребрәк, егет сымак торыш Хәятка мәхәббәтле күренделәр.* Ф.Әмирхан. *Күкрәкләр киңәеп китә, Иркенәя сулыш; Ныгый бара туган җиргә Горур басып торыш ---.* М.Әгъләмов. *Рухым үзенә яңа бер куәт, яңа бер дәрт алып, һәммә нәрсәнең төсе матурга таба үзгәрде; кулларым да, бөтен торышым да җиңеләеп, эшкә гайрәтем тәмам башкаланды.* Г.Гыйльманов

2) Билгеле бер нәрсәләрнең урнашу тәртибе. *[Нонаны] шакмаклы өстәлгә тезелгән фигураларның торышы --- кызыксындыра.* Азат хатын. *Авыл йортлары торышы*

3) *физ.* Җисемнең өчүлчәмле пространстводагы урыны һәм халәте. *Магнит кырының градиенты булганда, төрле торыштагы өч объект өчен өч ешлыкта сигнал тудырыла, һәм ул сигналларны Фурьеча үзгәртү өч резонанс сызыгы бирә.* Фән һәм тел. *Торыш геометриясе*

4) Билгеле бер халәт; берәр урында билгеле бер вакытта, билгеле бер хәлдә тукталып калу. *Борын астында --- йомшак кына мыек төкләре шәйләнгән егетнең оялчан торышы --- Камилгә үзенең үсмер чагын хәтерләтеп куйды.* М.Галиев. *Бу – кешенең бер торыштан икенчесенә күчүе генә, диде.* А.Нәҗми

5) *күч.* Кешенең, җанлы-җансыз нәрсәләрнең, вакыйгаларның яки эшнең билгеле бер вакыттагы хәле. *Ә соң машиналарга ремонт ясауның торышы куркыныч хәлдә түгелме?* Т.Гыйззәт. *Һава торышындагы зур аерымлыклар дымлылык шартларында күзәтелә.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТОРЫ́Ш-ЙӨРЕШ** *җый. и.* Сынгәүдә һәм йөреш. *Торыш-йөрешләре матур*

**ТОРЫ́Ш-КИЛБӘТ** *и.* Тышкы күренеш, кыяфәт, үз-үзен тотыш. *Аның бөтен торыш-килбәтеннән күңел нечкәрткеч гадилек, тиңлек, аеруча бер якынлык сизелеп тора.* К.Нәҗми. *Кечерәк буйлы җыйнак кына карт, иңбашлары әзрәк салынкы, кара көрән муенында аркылы-torкылы сызыклар, шуңадыр, ахрысы, ул бөтен торыш-килбәте белән каты агач тамырын хәтерләтә иде.* Казан утлары. *Комсомол җитәкчелегеннән күтәрелгәне бөтен торыш-килбәтеннән сизелеп торган президент үзенең чыгышын --- башлап җибәрде.* Мирас

**ТОРЫ́Ш-КИЛЕШ** *и. сир. к.* **торыш-килбәт**

**ТОРЫШЛЫЙ** *рәв.* Торган вакытта, торган моментта. *Ул, урыныннан то-*

*рышлый, яңадан бер кат көзгегә күз төшерде.* Ф.Әмирхан. *Кайсы тарафка атларга белмичә аптырап торышлый Заһитның башын тагын шундый эч пошулы уйлар биләп алды ---.* Җ.Юныс. *Хәлимгә Альбертның күзәтүчәнлеге һәм нәтиҗә чыгара белүе ошады. Урыныннан торышлый: – Моны үзегез уйлап чыгардыгызмы, әллә берәр кайдан ишеттегезме? – диде.* Ф.Яхин

**ТОРЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тору**. *Әти белән әнисе торышалар шаккатып.* Г.Тукай. *Баба ишектән керүгә, болар газаптан котылган кебек булып торыштылар.* Ш.Камал

2) Берәр нәрсәгә каршы тору, каршылык күрсәтү. *– [Алабай] бүрегә дә бирешми, – дип ышандыра [берсе], икенчесе: – Юк, бүрегә торыша алмас, – дип каршы төшә.* Н.Исәнбәт

**ТОСНАК** *и. тар.* 1) Йолым алу максаты белән яисә килешүнең үтәлешен тәэмин итү өчен әсиргә алынган зат; тотык, әманәт. *Сугышта тоснак алу*

2) Бурычларын түли алмагач, бурычка бирүчегә билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт итүче кеше. *Бурыч бирүчегә тоснак булу*

**ТОСТ** I *и. ингл.* 1) Мәҗлестә кем яисә нәрсә хөрмәтенә эчәргә тәкъдим итеп әйтелгән сүзләр, текст. *Я, хәзер кайсыгыз тост әйтә*? Т.Миңнуллин. *Беренче тост сезгә багышлана, егетләр. Илнең иминлеген, безне саклаучы батыр моряклар өчен ---!* Р.Кәрами. *Тост әйтүче, берсен алып, күп иттереп горчица сылады да бик канәгать кыяфәт белән ашарга тотынды.* Р.Сәгъди

2) Берәр кеше яки берәр нәрсә хөрмәтенә күтәрелгән эчемлекле бокал. *Шәһәрчә булсын дип, сөйли-сөйли тост күтәрәләр.* М.Мәһдиев

**ТОСТ** II *и. ингл.* Кыздырылган яки киптерелгән икмәк кисәге. *Өстенә кайнатма ягылган тәмле тост белән чәйләп алу*

**ТО́СТЕР** *и. ингл.* Тост (II) әзерләү җайланмасы. *Яңа тостер сатып алу*

**ТОТА́-КАБА** *рәв. сөйл.* Ашыгып, ашык-пошык, аны-моны уйламыйча. *– Алай тота-каба гына хәл итмәскә, бу турыда ныклап уйларга кирәк, – диде Фәйзулла.* М.Галәү. *Аның өлкән абзыйсы Галәветдин бакчаны болай тота-каба гына ботарлаттырмый.* А.Хәлим. *Амин тоткач та тота-каба торып китмәгез, мул, тәмле ризыклар биргәне өчен, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтегез!* Э.Шәрифуллина

**ТОТАКЛАТУ** *ф. диал.* Кешеләрне берсен икенчесенә тотындыру

**ТОТАКЛА́У** *ф. диал.* Ике кул белән тоту, кочаклау

**Тотаклап алу** Тиз генә тотаклау

**Тотаклап карау** Тотакларга тырышу

**Тотаклап тору** Даими яисә әледән-әле тотаклау

**Тотаклый башлау** Тотакларга тотыну

**ТОТАКЛАШУ** *ф. диал. к.* **тотынышу**. *Европада ике кызыл гигант тотаклашып юл чыкса, Франция белән Англиянең бик тиз сыннары катыр иде.* И.Гази. *Җитәкләшеп, тотаклашып Йөргән идек икәү Азия буйлап, Дуслар иле белән танышып.* Р.Фәйзуллин. *Сара ханымның Фәхри Насретдинов белән тотаклашып чыгуларын халык алкышлап каршы алды.* Сәхнә

**Тотаклашып тору** Тотаклашкан хәлдә булу

**ТОТАЛИЗА́ТОР** *и. фр.* 1) Ат чабышларында яисә башка төр спорт ярышларында теге яки бу атка, командага, спортчыга куелган акчаны (шулай ук куелган барлык сумманы) күрсәтә торган механик санагыч, счётчик. *Алга китеп шунысын да әйтик: яңа ипподромның хуҗасы – «Татспиртпром» берләшмәсе генераль директоры Рәшит Шәйхетдинов әйтүенчә, биредә йөздән артык тотализатор куелачак.* Татарстан яшьләре

2) Ипподромда җиңүче атларны фаразлаудан тупланган акчаны кабул итә һәм отышларны түли торган бюро. *Мин, атлар чабышын карарга баргач, тотализаторда да миллионнар калдырып кайтам.* Аманулла. *Тотализаторга чират тору*

3) Ат чабышларында яки башка төр спорт ярышларында җиңүчеләрне фаразлауга корылган акча уены. *«Корыч бабай»ның улы Василий Джугашвили, Казанга сөрелеп, генерал пенсиясен ипподром тотализаторына --- исраф итеп бетерде.* А.Тимергалин. *Ул гына да түгел, тотализатор уенын оештыручылар фикеренчә, «Ак барс» финалны 4:0 исәбе белән отачак.* Ватаным Татарстан. *Хокукый-гражданлык характерындагы килешүләр нигезендә, физик затларга хезмәт күрсәтү, лотерея, тотализатор һ.б. комарлы (азартлы) уеннардан кергән керемнәр дә декларацияләнә.* Шәһри Казан

**ТОТАЛИТАР** *с. сәяси* Җәмгыять тормышын һәрьяклап тулы, тоталь контрольдә тоту белән характерланган. *Без барыбыз да тоталитар режим, атеизм чорында тәрбияләндек.* Р.Вәлиев. *Соңгы көннәрдә матбугат та Татарстанда электән булган, әмма тоталитар система урнаштырылгач, Сталин вакытында ябылган Фәннәр академиясен торгызу хакында шаулады.* Ф.Яхин. *Тарихыбызның 70 еллык тоталитар дәвере сәхифәләрен актарганда әле һаман да бәгырең куырылып, тетрәнеп куясың: --- никадәр саф күңелле, эчкерсез, намуслы җаннар җинаятьчеләр өере тарафыннан хаксызга корбан ителгән икән бит!* Р.Әмирхан

**ТОТАЛИТАРИЗМ** *и. лат. кит.* Дәүләт тарафыннан җәмгыять тормышын тулы, тоталь контрольдә тоту белән характерланган сәяси режим, тоталитар режим. *Тоталитаризмга һәм җаһиллеккә каршы көрәштә ул немец халкының иң яхшы көчләренә таянган.* Р.Мостафин. *Хафизов --- Сталин тоталитаризмын фаш иткән әсәрләрне «каргышлы проза» дип атау ягында тора.* Ә.Закирҗанов. *Тоталитаризм чорының катгый кагыйдәләре буенча, әсирлеккә эләккән һәркем халык дошманы булып санала.* Гасырлар авазы

**ТОТАЛИТАРЛАШТЫРУ** *ф.* Тоталитар итү

**Тоталитарлаштыра бару** Әкренләп тоталитарлаштыру

**Тоталитарлаштырып бетерү** Тулысынча, бөтенләй тоталитарлаштыру

**ТОТАЛИТАРЛАШУ** *ф.* Тоталитар булып китү

**Тоталитарлаша башлау** Тоталитар якка таба үзгәрү

**Тоталитарлашып бетү** Тәмам тоталитарлашу

**ТОТАЛИТАРЛЫК** *и.* 1) Тоталитар булу. *Ил башының тоталитарлыгы*

2) Җәмгыять тормышының барлык өлкәләре дә дәүләт органнары тарафыннан тоталь (тулы) контрольгә алынган режим; тоталитаризм. *Русиянең өзлексез дәвам итеп килгән тоталитарлык режимы үз халкын интектергәндә, татарларга карата ясалма дошманлык пәрдәсен киң һәм актив файдаланып, ул интектерүне ни дәрәҗәгә җиткерүен чамалап була.* М.Гайнетдинов. *Кеше --- тоталитарлык богауларыннан арынып ирек алгач та мәңгелек рухи кыйммәтләргә кайталмыйча газаплана кебек.* И.Вәлиуллa

**ТОТАЛЫ́ ХАСТА** *и. сөйл.* Өянәк, зыяндаш авыруы, бума чире; эпилепсия. *Бала тумыштан тоталы хаста белән чирли*

**ТОТАЛЬ** *с.* **1.** Гомуми, һәркемгә, һәрнәрсәгә, мөмкин булган барлык очракларга кагылган, бөтен нәрсәне эченә алган; фронталь, тулы; тоташ. --- *тоталитар режим, шәһәр һәм авыл зыялыларына, аңлы эшче-крестьяннарга гына түгел, яшьләргә дә тоталь һөҗүм ясый.* Р.Вәлиев. *Тоталь глобальләшү зур, алдынгы, дәүләтле халыкларга куркыныч түгел ул.* Р.Миңнуллин. *Тик бала күңелендә шыткан көндәшлек хисе тора-бара тоталь көнләшүгә әверелергә мөмкин.* Ялкын

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Тоталь мобилизациягә эләккән солдат. *Чәй-кофе командасы кешеләре ул тотальләрне лагерь сакчылары арасында күреп тә кайтканнар иде.* Г.Әпсәләмов

**ТОТАМ** *и.* **1.** 1) Бер тапкыр учлап тотарлык күләм үлчәү берәмлеге (чама белән 10 см). *Җиде тотам ук атты.* Дастан

2) Дүрт бармак киңлегенә, якынча 7,2 см га тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Карачәчнең толымы – кырык бер тотам.* Н.Исәнбәт. *[Шәриф] Ботинкалар да бирделәр, тик шнуры гына бер тотам.* И.Салахов. *Гадәттә, курайларның озынлыгын тотам белән үлчиләр.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шул озынлык кадәр. *Гөлсәрия аңардан бер тотам да калмады, кай ягы беләндер үз итте ул аны – әле булса җавап таба алганы юк.* М.Хәбибуллин

2) Бер учка сыярлык, бер кечкенә бәйләм кадәр. *Үремгә кермәгән бер тотам маңгай чәче күзенә төшеп интектерә.* С.Зыялы. *Һәр мөэмин мөселманның бер тотам сакалы булырга тиеш, ди китап.* Р.Батулла. *[Олылар] атның җилкәсендәге бер тотам озын йонга уң куллары белән тотыналар.* Г.Галиев

**ТОТА́М БАВЫ** *и.* Ау лачыны аягына бәйләнгән тасма

**ТОТАМЛАП** *рәв.* Тотам-тотам итеп. *Тотамлап үлчәү*

**ТОТАМЛА́У** *ф.* Тотамнар берәмлегенчә үлчәү

**Тотамлап чыгу** Һәрберсен, булган берсен тотамлау

**ТОТА́М-ТОТАМ** *рәв.* **1.** Һәрберсе бер учка сыярлык кадәр, һәрберсен бер учка сыярлык итеп. *Өсләрендәге елкылдап торган йоннары, төсе уңып, тотам-тотам булып коела башлады.* М.Галәү

**2.** *с. мәгъ.* Тотамнар рәвешендәге. *[Аның] як-якка каерылып төшкән тотам-тотам чем кара озын чәчләренең торышыннан тиктормас, тынгысыз яшьлек күркәмлеге сирпелеп [куя].* Х.Госман

**ТОТА́М ТОТУ** *ф. к.* **тотышу** (*2 мәгъ.*). *Шуңа күрә малайлар я сөлге белән тотам тоталар, я саныйлар ---.* Ә.Фәйзи

**ТОТАНАК** I *и. сөйл.* Өянәк, зыяндаш авыруы, эпилепсия. *[Җинаятьче], әйтергә теләгән сүзе бугазына кадалып калган төсле, төкереген йота башлады. Бу үзенә күрә бер нерв тотанагы иде.* Г.Минский

**ТОТАНАК** II *и. сөйл. к.* **тотнак** (*1 мәгъ.*). *Ир нык ук төшергән, ахрысы, теленең тотанагы юк, улына дәрес бирә – тормыш белән таныштыра.* А.Гыйләҗев. *Телгә алай бик тотанагы булмаган бер кияү әзрәк салып килгән иде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев

**ТОТАНАКЛЫ** *с. сөйл. к.* **тотнаклы**. *Тыштан караганда бик сабыр, тотанаклы Сабирҗан абзыйсының болай тәэсирләнәчәген көтмәгән иде ул.* А.Хәлим. *Кешеләрнең рухы тотанаклы түгел, күңелләре зәгыйфь.* Г.Гыйльманов

**ТОТАНАКЛЫЛЫК** *и. сөйл. к.* **тотнаклылык**. *Хатыны киңәш иткән таблеткаларны эчкәч, эчендә политик тотанаклылык урнашкандай булды.* К.Кәримов. *Ләкин тотанаклылыгы җитмәде, адымнары тизәйгәннәнтизәя барды, һәм ахыр чиктә йөгерергә тотынды.* М.Кәбиров. *Ул үзенең тирән, күзәтүчән акылы, искиткеч ягымлылыгы, бары тик өлкән буын әдипләргә генә хас булган тотанаклылык, итагатьлелек белән мине һәрчак таң калдыра иде.* Татар әдипләре

**ТОТАНАКСЫЗ** *с. сөйл. к.* **тотнаксыз**. *Кинәт кенә бер-бер хәл булыр да, дөньяның асты өскә килер, күк йөзләре кара корымга әйләнер, аяк асты тотанаксыз көймә кебек чайкалыр, һәм тирә-якта караңгы баз булыр кебек иде Тимергә.* Г.Рәхим. *Боларның авылларында Гыйльмаз исемле бик дуамал, тотанаксыз ир яши икән.* З.Мурсиев

**ТОТАНАКСЫЗЛЫК** *и. сөйл. к.* **тотнаксызлык**. *Изделәр безне, сәяси тотанаксызлыкта да гаепләделәр ---.* Р.Батулла. *Батулланың Исхакые әлеге әсәрләрдә якланган фикерләрне кире кагып кына калмый, аларның кеше тәрбияләүдәге зыянын, начар үрнәк булуын да искәртә: «Бөтен дөнья шушы тотанаксызлыкны мактый».* Ә.Закирҗанов. *Женси һәм әхлакый тотанаксызлык – бүгенге җәмгыятьне җимерүче көч.* Җ.Харисов

**ТОТАШ** *с.* **1.** 1) Киселмичә, өзелмичә, бүлгәләнмичә сузылган яки җәелгән (мәйдан, сызык, өслек, масса тур.); дәвам иткән (вакыт тур.). *Елга өсте елдан-ел тоташ саз үләне белән каплана бара, шуның белән бергә аның алдавыч хәтәр урыннары да күбәйгәннән-күбәя.* М.Галәү. *Кайшалып үскән клевер басуы урман полосасына кадәр тоташ диңгез булып җәелеп яткан.* М.Мәһдиев. --- *әтием тоташ унбишәр көн Себердә эшләгән чагында, әнинең бик еш туганнан туган тиешле сеңелләренә кунакка йөрүендә булмады микән?* Э.Шәрифуллина

2) Аерылгысыз зур кисәк рәвешендәге. *«Салават Юлаев» пассажирлары, тоташ агым булып, безнең пароходка керә башладылар.* Р.Батулла. *Тоташ кыя*

3) Туктаусыз, бер өзлексез эшли, башкарыла торган. *Якын киләчәктә без механика цехын тоташ агымга күчерергә тиешбез.* Г.Әпсәләмов

4) Бөтенесен чолгап алган, гомуми; массакүләм. *Капитализмның безнең илдәге соңгы вәкиле булган кулакларны тоташ колхозлашу нигезендә сыйныф булу ягыннан бетерү сәясәтенә күчтек.* М.Җәлил. *«Половник» яки «плауник» дип, тоташ төбәге белән сөйләшүче татарлар юк; авыл җирендә анда-санда гына сөйләшәләр.* Х.Сарьян. --- *республикабызда тоташ газлаштыру башлангач, халык ничек шатланган иде, газның бәясе шалкан бәясе генә иде әле ул чорларда.* Татарстан яшьләре // Тулы. *Тоташ аклыкка әйләнеп тулышкан күз яшьләре тәгәрәп сукмакка төште дә челпәрәмә килде.* М.Галиев

5) *күч.* Характеры, эшләре һ.б. ягыннан икенче берәү белән бер бөтен тәшкил иткән, үзара тоташкан; аерылгысыз. *Ул Мәдинәне үзенең тоташ бер кисәге төслерәк якын хис итә.* Ш.Камал

6) *күч.* Гел, бары тик бер нәрсәдән генә торган. *Илчеләр арасында чалма ураганнары да, тәре такканнары да, тоташ күгелҗем карадан киенгән ламалар да бар.* М.Хәбибуллин. *Плащлар төрле төстә булса да, диңгез буендагы чуерташлар кебек бергә килгәч, тоташ бертөсле – күксел соры булып тоелалар.* М.Маликова. *Кеше язмышының тоташ сынаулардан торганын яшь кыз каян белсен соң?* Д.Каюмова

7) *күч.* Күп, зур суммалы, вакланмаган. *Кайтыр алдыннан, хатын тоташ акчаны алып бетерә миннән.* З.Зәйнуллин. *Аннан тагын берәр нәрсәгә тоташ акча кирәк булып куюы да бар бит.* С.Әдһәмова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бүлгәләнмичә, өзелмичә. *Маңгае буенча тоташ сузылган куе кара кашлы --- бу кешенең бөтен хәрәкәтендә --- кыюлык бар.* А.Шамов. *Тавык яки үрдәкне тоташ килеш суда ярым пешеп җиткәнче пешерергә.* Татар халык ашлары

2) Туктаусыз, бер өзлексез; бертоташтан, рәттән. *Празат абыйны җиргә иңдерәсе көнгә каршы төн буе һәм икенче көнне тоташ кар яуды.* Идел

3) Тулысынча, бөтенләй, бөтенләе белән. *Итегемнең кунычлары ак килеш калса да, түбән ягы тоташ пычракка баткан, буялып, бозланып каткан.* Г.Бәширов. *Бүген аның тормышы тоташ ялганнан гына гыйбарәт.* Н.Гыйматдинова

4) Бер-берeнә тиеп; кушып; кушылып; күрше, янәшә, чиктәш булып. *Артк ы өй алдагы зур өй белән тоташ иде.* М.Акъегет. *Судьялар бүлмәсе белән присяжныйлар бүлмәсе бер-берсенә янәшә һәм тоташ булганлыктан, хөкем карары чыгарылганчы берни нди очракта да очрашырга тиеш булмаган кешеләр, бу кагыйдәне бозып, бик тиз аралашып беттеләр ---.* М.Галәү. *1768 елда исә, Екатерина II карары нигезендә, әлеге манарага тоташ итеп, таштан бер катлы яңа мәчет салынган.* Гасырлар авазы

**ТОТАШКА** *рәв.* Тәнәфессез, өзлексез. *Яшь-яшь кызлар фронтка снарядлар ясыйлар, көненә 12 шәр сәгать тоташка эшләргә туры килә аларга.* Безнең мирас // Туктаусыз. *Дүртебез генә кич утырган чакларда, Нургалинең мине тоташка назлап торуыннан Сәҗидә бераз көнләшеп тә куя иде шикелле.* Г.Галиева

**ТОТАШКАН** *с. физ.* Бер-берeнә тоташтырылган һәм сыеклык берсеннән икенчесенә күчә ала торган. *Тоташкан савытлар теләсә нинди формада булсалар да, алар эчендәге тыныч сыеклыкның иркле өслеге бер үк биеклектә була.* Физика. *Ә тоташкан савытлар теориясе аның тарафыннан тулысынча иҗат ителә.* Фән һәм тел

**ТОТАШЛЫЙ** *рәв.* 1) Аермыйча, бүлмичә, бөтен, тоташ килеш, тулысынча. *Теге якта --- тоташлый куелган яшел буяулы тимер чардуган, анда куе канәфер куаклары үсеп утыра ---.* Ә.Гаффар. *Тоташлый каплаганмы, өзлексез агучанмы – күзгә болытмазарга, кар явулар, сыкы төшүләр, томаннар, бозлавыкларга карамастан, ул шулай итүчән.* Сөембикә

2) Бөтенләй, тәмам. *Кылынасы кылынмау, тормыш рәхәтлекләрен татырга өлгермәү турындагы уйларга барып җитү Сауранны аңына-акылына тоташлый кайтарды.* М.Хуҗин.

3) Туктаусыз, өзлексез. *Үткән атнада гына тоташлый яуган яңгырлар җирнең бар тузанын юган.* Казан утлары. *Шуннан соң төннәр буена тоташлый очкылык тотып чыга инде.* Ватаным Татарстан

**ТОТАШЛЫК** *и.* 1) Тоташ булу; бөтенлек. *Ярык агач материалның тоташлыгын боза, механик ныклыгын һәм озакка чыдамлыгын киметә.* Төзү материаллары. *Манара вертикальдән авышуның төп сәбәпләре берничә: --- яссы ташлардан салынган һәм арасына вак таш һәм балчык тутырылган нигезнең кысылу деформациясе нәтиҗәсендә тоташлыгы бозылу, манара урнашкан калкулыкның күчүе.* Фән һәм тел

2) Эчке берлек, эчке бөтенлек, икеләнүсезлек. *Ул, кайчан карама, матур бер көй көйләп йөри, --- аның хәрәкәтләрендә дә күңел кузгаткыч бөтенлек, тоташлык бар.* Г.Ахунов. *Дингә инанучыларның картлык көннәре күпкә куанычлырак. Аларның күңелләрендә эчке бер тоташлык, рухи комфорт яши...* М.Юныс

3) Кайсы яктан булса да үзара бәйләнгәнлек. *Ышанасы, инанасы килү – безнең канда. Ансыз яшәүнең киләчәк белән тоташлыгы калмый. Киләчәксезлек – шулай ук мәгънәсез яшәү.* М.Юныс. *Аларны югалтканнан соң, тарихыбыз белән тере тоташлыкны җуйгандай булдык.* Гасырлар авазы

**ТОТАШМА** *и. физ.* 1) Бер-берләренә тоташкан, ялганган, береккән җисемнәр, детальләр. *Исемнәр бит алар хәрефләр тоташмасы гына.* Р.Нуруллин

2) Шундый җисемнәр, детальләр үзара тоташкан, ялганган урын // Кушылган, ялганган нәрсә

**ТОТАШТАН** *рәв.* 1) Рәттән, бер өзлексез, туктаусыз, бүленмичә. *Аңардан котылып бераз үтүгә, тоташтан берничә көн кар яуды.* Г.Ибраһимов. *Сәүдә бизгәге шулай берничә атна тоташтан дәвам итә.* М.Галәү. *Яңгыр тоташтан койды...* М.Мәһдиев

2) Һәрвакыт, гел. *Ахыргы җөмләне абыстай татар кызының колагына ике ел тоташтан кычкырып торды: – Ирләр сиңа фәләнчә карыйлар!* Ф.Әмирхан. *Игелеккә тоташтан*

*начарлык белән җавап бирү, күпме генә тырышса, ни генә эшләп караса да, һаман рәхмәтсез булып калу әтиемне көннән-көн үзенә ныграк бикләнергә мәҗбүр иткәндер.* Ә.Шәрифуллина

3) Булган берен, барысын да. *Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр.* Ә.Еники. *Әнә шул варварлар безнең ерак бабаларыбыздан калган сыннарны тоташтан диярлек юкка чыгарып барганнар.* Р.Вәлиев. *Кайсысы шар тәгәрәтә башлый, кайсысы стенаны тоташтан каплап алган «Тынгысыз каләм» гәҗитен укып рәхәт чигә.* Р.Зәйдулла

**ТОТАШТЫРГЫЧ** *с.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса беркетү, тоташтыру өчен хезмәт итә торган. *Ябыштырган урында тоташтыргыч катлам барлыкка килә.* Төзү материаллары. *Завод тоташтыргыч приборлар җитештерү буенча башта СССРда, хәзер Россиядә төп предприятие булып тора.* Ватаным Татарстан

2) *биол.* Тере организмнарда күзәнәкара матдәләре булган һәм саклау, терәк, шулай ук тукландыру функциясен үти торган тукыма. *Мускуллар системасы тоташтыргыч тукымадан торган бүлгеләр белән сегментларга бүлгәләнгән.* Биология. *Бу вакытта, кан тамырлары стеналары тоташтыргыч тукыма белән каплану нәтиҗәсендә, тамыр куышлыгы тарая, һәм кан йөреше акрыная.* Ватаным Татарстан

**2.** *и. мәгъ.* Электр тогын тоташтыра торган җайланма. *Мансур телевизор алдында утырып, тоташтыргычын боргалый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Түбә ышыгына беркетелгән электр тоташтыргычы төймәсенә басып, Мирзахан абзарга ут кабыза да, кабаланып, йозакларны ача.* С.Зыялы

**ТОТАШТЫРМА** *и.* 1) *тех.* Берәр нәрсәнең аерым кисәкләрен үзара тоташтыра торган өлеше, детале. *Тоташтырма, эчке дивар, кәрниз, колонналар куйганда, марканы 100гә кадәр арттырырга мөмкин.* Төзү материаллары

2) **тоташтырмалар** *күпл. мат.* Үзләре яки үзләренең тәртипләре белән бер-берсеннән аерылган саннарның төркемнәре (мәс., 123, 321, 1965 һ.б.)

**ТОТАШТЫРМАЛЫ** *с. тех.* 1) Тоташтырма ярдәмендә эшли торган, тоташтырмасы булган

2) Үзара яисә нәрсәгә дә булса тоташтырыла торган. *Тоташтырмалы җиңсә. Тоташтырмалы яка*

**ТОТАШТЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәләрне дә булса үзара яки кечерәген зуррагына ялгау, кушу. --- *җир белән күкне тоташтырып телгәләгән яшен камчылары --- астында япа-ялгыз калган Өянке исән калуына инде тәмам ышанычын җуйган иде.* М.Галиев. *Бу юлы үлем палатасына ук кертеп салдылар, баш очына пыяла савытлар элеп чыктылар, аларны кан тамырларына тоташтырдылар...* Г.Гыйльманов. *Аксуны икегә бүлеп аккан елга ярларын асылмалы күпер тоташтыра.* Г.Әдһәм

2) Теге яки бу элемтә чарасы яки юл ярдәмендә үзара бәйләнеш, элемтә, бағланыш урнаштыру. *Зинһар, миңа Садрый Атабаевның конторын тоташтырыгыз әле.* Г.Камал. *Мисс, сезнең белән Лондоннан Марго Фонтейн сөйләшергә тели, тоташтырам... Элемтә урнашты, элемтә урнашты, тоташтырам...* Р.Батулла

3) *физ., тех.* Энергия чыганагына ялгау. *Асия үтүкне электрга тоташтырды.* Р.Кәрами. *Почмакта басып торучы Роботны токка тоташтырам.* Р.Батулла. *Екатеринбургта психиатрда исәптә торучы хатын --- мумиягә әйләнгән туганының гәүдәсенә, терелтәм дип, электр чыбыклары тоташтырып, янгын чыгарган.* Мәдәни җомга

4) *куч.* Сүз яки фикер агышын, вакыйгалар үстерелешен берәр нәрсәгә китереп бәйләү, ялгау, билгеле бер нәтиҗәгә китерү. *Бу әдәбиятның логик үсеше аларны контрреволюциягә, кара реакциягә китереп тоташтырды.* М.Җәлил. *Әсәрләрдә бүгенгене үткән белән тоташтырып, хәзергене борынгы белән сугарып, хәтер көче аша буыннарны рухи берләштерергә, милләтнең бүгенге вәкилләренә үткән хакында сөйләп, бүген үз-үзләре белән горурланып яшәүләренә ирешү омтылышы сизелә.* Р.Гали

**Тоташтыра бару** *к.* **тоташтырып бару**. *Камил ике күңел түтәлен дуслык гөлләре тоташтыра баруын күреп бик сөенде.* Ф.Яруллин. *Башта «сәхнә» барлыкка килә, аңынчы монда экскаватор да эшләп алган, белгечләр дә хезмәт куйганнар: ташларны берберсенә беркетеп тоташтыра барганнар, һәм гаҗәеп күңелле түгәрәк хасил булган.* Ак калфак

**Тоташтыра башлау** Тоташтырырга керешү. *Ул, йөгереп барып, компьютерларын тоташтыра башлады, тегеләре серле итеп гүләргә, гөҗелдәргә тотындылар.* Ф.Бәйрәмова. *Машинаны күтәртеп, мастерлар яңа тросны тоташтыра башлаганнар иде дә, бу тормоз колодкалары, имеш, инде ашалган, яңаларны куймыйча булмый, дип таптылар.* Татарстан яшьләре

**Тоташтыра тору** Берәр эш-гамәлгә кадәр тоташтыру яки әледән-әле тоташтыру

**Тоташтырып алу** Кыска вакытка, тиз генә тоташтыру. *Шуңа күрә аларны ике-өч көнгә бер мәртәбә электрга тоташтырып алырга туры киләчәк.* Татарстан яшьләре

**Тоташтырып ату** Тиз генә, аннанмоннан тоташтыру

**Тоташтырып бару** Бер-бер артлы, рәттән тоташтыру. *Бискорню өлешләрен канвасыннан текмибез, читләрен билгеләүче җепләрне тоташтырып барабыз.* Л.Хаҗиева

**Тоташтырып бетерү** Барысын да, ахырга хәтле тоташтыру. --- *торбаларны тәмам тоташтырып бетергәч тә китәчәк Тәбрик.* Ә.Баян. *Тагын ике елдан республикадагы барлык мәктәпләрне яңа челтәрле Интернетка тоташтырып бетерәчәкләр.* Ватаным Татарстан. *Анысын һич икеләнүсез әйтә алам: бөтен чәчәк-ботакларны бергә тоташтырып бетергәч, гөл яки агачның нәкъ син теләгәнчә килеп чыгуын күрү – иң рәхәт мизгел!* Шәһри Казан

**Тоташтырып җибәрү** Бер тапкыр яисә тиз арада тоташтыру. *Су кертергәме?.. Артык булмас, мөгаен. Кертергә туры килер. Канализациягә дә тоташтырып җибәрсәң...* Җ.Юныс. *Аның кушуы буенча магнитофонны комиссия әгъзалары уратып утырышкан өстәл уртасына куйдым, тоташты-*

*рып җибәрдем.* Ф.Баттал. *Язучы биредә берничә төр хикәяләүне тоташтырып җибәрә ---.* Әдипләр

**Тоташтырып карау** Тоташтырырга тырышу. *Беркөн әти эштән шатланып кайтып керде, аңа яңа кабина биргәннәр икән. Ә электрикасын тоташтырырга кеше юк. --- Мин, әйдә, икәү тоташтырып карыйк, дигәч, башта булдыра алмам дип курыкты.* Гасырлар авазы

**Тоташтырып килү** Озак вакытлар дәвамында, күптәннән бирле тоташтыру. *Гәрчә аның [автобусның] йөрүе бик канәгатьләнерлек булмаса да, ул ничә еллар буе бистәне шәһәр белән тоташтырып килде.* Ватаным Татарстан

**Тоташтырып кую** Алдан ук тоташтыру; тиз генә тоташтыру. *Менә шул синең тамганы алдарак буялган бер тамга белән тоташтырып куйдылар.* Г.Гыйльманов. *Париждан, залга эләргә дип, люстра алып кайткан идем. Җыюын җыйдым, тик элеп, тоташтырып куярга җөрьәт итмәдем.* Г.Шәмсетдин

**Тоташтырып тору** Хәзерге моментта яисә даими тоташтыру. *Очрашкан юк, күреп сөйләшкән юк. Хатларың да килми күптәннән. Күңелемнең ике ярын бары Тоташтырып тора үткәннәр.* Х.Туфан. *Берсенә берсен тоташтырып торган аркылы араталары янып өзелгәч, --- берегеп торган манара баганалары кинәт таркалалар ---.* Т.Мөбарәков. *Сабак терәк ролен үти, үсемлекнең барлык өлешләрен тоташтырып тора; сабак буйлап су, минераль һәм органик матдәләр хәрәкәтләнә.* Биология

**Тоташтырып чыгу** Башыннан ахырынача, һәрберсен бер-бер артлы тоташтыру. *Казан тирәсендәге авылларга күн таратылган, һәм хатын-кызлар төрле төстәге күннәрне ат кылы төсле ефәк белән тоташтырып чыккан.* Казан утлары. *Шулай итеп, өлешләрне җөйләреннән тоташтырып чыгабыз.* Сөембикә

**ТОТАШУ** *ф.* 1) Үзара бер бөтен тәшкил итү, нык орынып тору, ялгану. *--- аның бөтен өмете менә шушы камера игәүләп утыручы дәү башлы, нечкә муенлы, кашларына ук диярлек тоташып үскән куе кара чәчле --- адәмгә бәйләнгән.* В.Нуруллин. *Күзәнәкләр бер-беренә орынып торалар һәм янәшә күзәнәк тышчалары арасындагы махсус күзәнәкара матдә белән үзара тоташканнар.* Биология. *Фикусның яфраклары ялтырап, ямь-яшел торсын дисәң, гөлнең кәүсәсе белән тамыры тоташкан урынга бер бал кашыгы кастор мае сибеп җибәрегез.* Йорт эшләре

2) Турыдан-туры һәм тыгыз чиктәш булу. *Шулвакыт әче таң җиле исеп китә, еракта карның таң кызыллыгы белән тоташкан җирендә ниндидер шөбһәле тавыш ишетелеп куя ---.* М.Мәһдиев. *Ә тагы да арырак, бакчаның Иделгә төшеп тоташкан куенында, чарт та чорт килеп, коры каен утыны дөрләп яна...* Р.Мөхәммәдиев. *Зиратка тоташып диярлек кечкенә чирәмлек җәйрәп ята.* Р.Кәрами

3) Икенче бер зуррак һ.б.ш. нәрсәгә кушылу яисә шуның белән чиктәш, янәшә тору. *Әмма иң кызыгы алда – ферма бинасының ике канаты килеп тоташкан урталыкта икән.* М.Хәсәнов. *Чабышка килгән атларны Сорна урманының басу белән тоташкан урыныннан, киң юл буйлап, кардон өенә якын ачыклыкка алып киләләр.* Г.Галиева

4) Берегү, ябышу. *[Кыя] җиргә бик нык тоташкан, Көчне ул ала җирдән.* Ә.Ерикәй. *Җиргә тоташып кату*

5) Елгага, күлгә яки диңгезгә кушылу, кою. *Зур сулар диңгезләргә тоташа.* Физик география. *Безнең елга зур елгага барып тоташа бит.* Сабантуй. *Еллар үтеп, кеше таный башлагач кына, әбием сөйләгән Туфанның мөхтәрәм драматург Туфан Миңнуллин булуын аңладым һәм Татарстанның Идел белән Кама тоташкан иң гүзәл районында тууым белән чиксез горурланып йөри башладым.* Безнең гәҗит

6) Теге яки бу элемтә чарасы ярдәмендә бәйләнешкә (багланышка) керү. *Лейтенант Сабитов, телефон аша комендатура белән тоташып, кыскача гына рапорт бирде.* Г.Минский. *Бөтен мәктәпләр дә югары тизлекле Интернетка тоташкан.* Идел. *Вахит галәмара Интернет челтәренә тоташырга азаплана.* Сабантуй

7) *күч.* Өзеклек булмау. *Айныкы айга тоташып кына бара, бер дә акча калдырып булмый.* М.Гали

8) *күч.* Кайсы яктан булса да берәр нәрсә белән бәйләнешкә (багланышка) керү. *Аның иҗаттагы вак буржуа позицияләреннән пролетариат социалистик әдәбиятына килеп тоташкан юлы шактый катлаулы, авыр һәм борылмалы булды.* М.Җәлил. *Болай да яшәеш шул шыгырдавык акчага барып тоташкан.* А.Гыйләҗев. *Әнием – Русиядә һәм хәтта чит илләрдә дә танылган шагыйрә Анна Ахматова – нәсел җебе – шәҗәрәсе белән Алтын Урда ханы Әхмәткә барып тоташкан.* М.Хәбибуллин

9) *күч.* Бербөтен булу, бөтенлек тәшкил итү. *Либераль буржуазия музыканың киң халык иҗаты белән тоташып үсүенә --- каршы тора.* М.Җәлил. *Шатлык белән шатлык үзара охшашлар, алар кайдадыр бер урында тоташып, кушылып китәләр.* М.Мәһдиев

**Тоташа бару** Торган саен ныграк тоташу. *Язучы Ф.Хөсни --- мәкаләсендә документаль юнәлешнең үсешен «бик вакытлы күренеш» дип билгеле һәм аның сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: «Беренчедән, буыннар белән буыннар арасындагы багланышның тоташа баруы --- гәүдәләнә монда».* Г.Гайнуллина. *Н.Фәттахның Фест дисбесен укуга багышланган тарихи-фәнни лингвистик хезмәте милләтебезнең ерак гасырларга тоташкан эзләрен ачыклау юнәлешендә зур ачыш булып тора.* Фән һәм тел

**Тоташа башлау** Аз гына, бераз тоташу; тоташу билгеләре сизелү. *Көнчыгыш участоклар тоташа башлады.* С.Шәрипов. *Иманлы, ныклы нигезгә корыласы мөселман гаиләләренең елдан-ел күбрәк таркала баруының бер сәбәбе дә шушы матди якка барып тоташа башлады.* Шәһри Казан

**Тоташа язу** Аз гына тоташып бетмәү; тоташырга аз гына калу. *Шулай әйләндереп, канатларны бер-беренә терәп бәйләп чыккач, беренче белән унынчы бер-берен урап килеп тоташа яздылар, тик аршын ярым киңлегендә ачык урын калды.* Г.Ибраһимов. *Әгәр*

*дә борын өстендә тоташа язган куе кара кашлары чыраена усаллык өстәп тормаса, аңа карап сокланырга гына калыр иде.* Н.Көбәш

**Тоташып бару** Акрынлап тоташу, тоташа башлау. *Моннан унике ел элек атау елганың уртасында тора иде, хәзер әнә сул як ярга тоташып бара инде.* С.Сабиров

**Тоташып бетү** Тулысынча, тәмам тоташу. *Бу авыл безне үз балалары кебек якын итте, әти-әниебез дә, без дә аны бик яраттык, бөтен күзәнәкләребез белән аңа тоташып беттек.* Л.Шагыйрьҗан. *Имеш, бу күлләрнең суы җир астыннан үзара тоташып беткән, алар хәтта Җидесу елгасына кадәр саркып чыгалар, ди...* Г.Гыйльманов. *Тиздән авыл мәктәпләре барысы да Интернетка тоташып бетәчәк.* Татарстан яшьләре

**Тоташып җитү** Тиешле дәрәҗәдә тоташу. *Ипиләренең берсе зур, башкасы кечерәк килеп чыкты, өсләрен шомарта алмыйча интекте: әвәли дә әвәли, камыр аның саен тоташып җитми, йомры кумәч хәленә килми.* К.Тимбикова

**Тоташып калу** Берәр тәэсирдән соң тоташкан хәлгә килү. *Менә карагыз: электроплитәгез токка тоташып калган бит.* Ф.Яруллин

**Тоташып килү** *к.* **тоташып бару**

**Тоташып китү** Әкренләп бөтенләй тоташу. *Кайбер урыннарда ул чокырлар артык ешаеп, бер-беренә тоташып китә.* Р.Мостафин. *Җилкәләре киң генә түгел, бик киң, Хода бер кешегә ике кешенең җилкәсен биргән кебек, муены башы белән тоташып киткән диярлек.* М.Хәбибуллин. *Чем кара, сиртмәле бөдрә чәчләр шундый ук чем кара ай кашлар белән тоташып ук китәләр.* Г.Гыйльманов

**Тоташып кую** Алдан ук тоташу; тиз арада тоташу

**Тоташып тору** Даими, һәрвакыт тоташу, әледән-әле тоташу; гомумән тоташкан хәлдә булу. *Кыз син дә мин: куе кашлары тоташып тора, бөдрәләре кабарынкы.* Р.Камал

**ТОТЕМ** *и. ингл.* Берәр ыру, кабилә, билгеле бер төркем кешеләр табына торган хайван, үсемлек, әйбер яки табигать күренеше һәм шуның сурәте, сыны (мәс., эт, бүре, ат, яшен һ.б.). --- *әлеге әкияттәге Ак бүре – тотем, билгеле бер ыруны яки кабиләне башлап җибәрүче генә түгел (ата-бабалар культы), ә бәлки аннан югарырак, мәҗүси алла дәрәҗәсендә торган зат.* Ф.Урманчеев. *Римны төркиләрнең тотемнары булган бүре белән каз саклаганы да билгеле.* Р.Һади

**ТОТЕМИЗМ** *и. рус* Тотемнарга табынудан гыйбарәт ышану системасы. --- *хәзерге рәсми дөньякүләм диннәр анимизм, тотемизм, магия, ата-бабалар культы кебек карашларның байтагын үзләштерә һәм үз тәгълиматы таләпләренә буйсындыра ---.* Ф.Урманчеев. *Мондый борынгы дин тотемизм (әйбергә табыну) дип атала.* Р.Фәхретдинов

**ТОТЕ́МИК** *с.* Тотемга мөнәсәбәтле, тотемга нигезләнгән. *Ак бүренең болгар кабиләләренең тотемик нәсел башы булуы да ихтимал ---.* Ф.Урманчеев. *Богарыслан исеме кеше белән хайваннарның килеп чыгышлары уртак, дип карауга нигезләнгән борынгы тотемик дини ышануга барып тоташа.* Совет мәктәбе

**ТОТЕМИ́СТИК** *с.* Тотемизм белән сугарылган яки тотемизмга бәйләнгән; тотемик. *Борынгы төркиләр, мәҗүси (тотемистик) ышану һәм йола белән бәйләнешле рәвештә, бүре сүзенең синонимы булып йөргән кашкар, качкар, корт, монгол теленнән кергән ашап һәм чаны сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар.* Татар халык иҗаты. *Г.Ф. Саттаров антропонимикада бүре сүзе белән бәйле исем-фамилияләрнең килеп чыгышын борынгы бабаларыбызның тотемистик ышануларына бәйләп аңлата.* Фән һәм тел

**ТОТКА** *и.* 1) Күтәреп йөртү, тоту, ачу-ябу, тартып күчерү өчен, нәрсәгә дә булса беркетелгән һәм гадәттә кыска гына ярымдуга рәвешендәге махсус сап. *Маннур, --- кесәсеннән җыелмалы метр чыгарып, бидоннарның озынлыгын, төбенең киңлеген, тоткасының биеклеген үлчәп язып алды.* М.Хәсәнов. *Зур балчык чүлмәкне бау белән бәйләп, тотка ясап, бер кулга тоталар.* З.Зәйнуллин. *Ләкин аның кулыннан тотка йолкынып, кинәт кенә ишек ачылып китте.* Н.Яһудин

2) Сугыш яки эш коралларының тоткычы, сабы. *Тәмәкене бер читкә ыргытып, револьвер тоткасын кысып тоттым да җәһәт кенә мәгарә авызына килдем һәм эчкә күз ташладым.* Р.Вәлиев. *Буй пычкының аркылы тоткасына кулы тию белән, егеткә дәрт керә.* Д.Каюмова

3) Баскычның ян ягына беркетелеп, күтәрелгәндә-төшкәндә кул белән тотыныр өчен, агачтан яки металлдан эшләнгән җайланма; торык; култыкса. *Габдулла туктады һәм баскычның тоткасына тотынган хәлдә артына борылып карады.* Ә.Фәйзи. *Аттан сикереп төште дә Зиннур аны мәктәпкә керә торган баскыч кырыендагы агач тоткага бәйләде.* З.Зәйнуллин

4) Машиналарны, аппаратларны, эш коралларын хәрәкәткә китерү яки туктату өчен көйләнгән, кул белән борыла торган җайланма. *Әзһәт резин шлангның бер башын мичкәгә төшерде дә, олы чан янына килеп, --- насосның агач тоткасына ябышты.* Р.Кәрами. *Билгеле, аңа яңа сигезенчене тәмамлаган баланың көче җитәрлек түгел: хәтта олылар да кайчак, моторны эшләтеп җибәрү өчен, әлеге кәкре тоткага икәүләп тотыналар иде.* Р.Гаязетдин

5) *күч.* Ышанычлы терәк; таяныч. *Шулай булмыйча мөмкин дә түгел иде: кыска гына вакыт эчендә Шәрәф безнең газетаның тоткасы булып әверелде.* М.Яһүдин. *Сыйныфның лидеры булып, педагогик җитәкчелексез килеш сабакташларына йөгәннән ычкынырга ирек бирмәгән класс тоткасы Альбина үзе дә Фәнистән күзен ала алмады.* Ш.Алпар

6) *күч.* Төп терәк, нигез. *Ил тоткасы булган ирләрне чалгы белән чапкандай кыралар.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә кайчандыр ул тирәдә яшәүче халык ислам диненең тоткасы булган.* Т.Нәбиуллин. *Гадәттә без, каләм ияләре, дөньяның тоткасы – гади халык, хезмәт кешеләре, дигән гыйбарәне алга чыгарып куярга яратабыз.* Р.Фәизов

**ТОТКАВЫЛ** *и. тар.* 1) Тышкы сакчы, капка яки ишекнең тышкы ягында

торган сакчысы. *Капуда торган тоткавыл, Тоткавыллар белән сөйләшеп Үтеп керде Норадын. Идегәйнең ак сарай – Җитеп килде Норадын.* Дастан. *Анысын син инде бар да әнә капка төбендәге тоткавылдан сора.* Н.Исәнбәт. *Тоткавылның төп максаты-вазифасы Хансарайга шикле кешеләрне кертмәү булып, керткәндә дә тентеп-тикшереп кертү иде.* Р.Батулла

2) Саклык чаралары күрү һәм күзәтчелек эшләре алып бару өчен билгеләнгән кечкенә отряд

**ТОТКАК** *и. сөйл.* 1) Кискен өянәк. *Эпилептикның тоткагы башлану*

2) Өянәкле авыру. *Аның тоткагы бар икән*

3) Бала табу алдыннан була торган авырту, тулгак

**ТОТКАКЛЫ** *с. сөйл.* Өянәкле

**ТОТКАЛЫ** *с.* Тоткасы булган. *Бала, чыннан да, ник сусаган иде. Йотлыга-йотлыга, ике кулы белән тоткалы чүлмәккә ябышып эчте дә эчте.* З.Зәйнуллин. *Баксаң, һаваланып киткән генерал, спорт киеме астындагы кобурадан алтын тоткалы пистолетын чыгарып, шарт та шорт күккә төбәп атырга керешкән булып чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**ТОТКАР** *и.* Максатлы хәрәкәтне, йөрешне-барышны, омтылышны тоткарлый торган сәбәп, комачау, киртә; тоткарлык. *Килеп тотты бер тоткар, Менә ул мине тукмар.* Такмаза. *Сезгә акча дисәң – акча хәзер, ат дисәң – ат хәзер, берсендә дә тоткар юк.* С.Җәлал. *Сиңа каршы торырлык көч һәм дошман, сиңа тоткар булырлык киртә һәм корган юк.* Әдипләр

◊ **Тоткар булу** Кемгә яки нәрсәгә дә булса комачау итү. **Тоткар салу** 1) *бор.* Дошман юлында һәртөрле киртәләр кору; 2) Махсус рәвештә комачаулау

**ТОТКАР ИТҮ** *ф.* Тоткарлау, комачаулау, киртә булу. *Киңәшчемнең хикмәтле сүзләре Тоткар итә һаман кулымны.* Ф.Бурнаш. *Анда китүне тоткар итәрлек минем бер гаебем дә юк.* Т.Гыйззәт. *Зиһенебезне шулкадәр мәшгуль һәм тоткар иткән бу әсәргә кайчак шулай бер роман укырлык вакыт китә торган булса, аның турында «Үзе кечкенә, эче төш кенә» дигән сүз бик туры килә.* Н.Исәнбәт

**ТОТКАРЛАГЫЧ** *с.* **1.** Тоткарлый торган. *Бу очракта, йөрәк аша даими электр агымын үткәргәндә, гизүчән нервның йөрәккә тоткарлагыч йогынтысы кимеми.* Фән һәм тел. *Тоткарлагыч чаралар. Тоткарлагыч вал*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Нәрсәне дә булса тоткарлый торган җайланма, әйбер. *Авыш транспортёрның ияртүче валы белән иярүче валы арасына фанердан ясалган тоткарлагыч куйдылар.* Казан утлары

2) *к.* **тоткарлама**

**ТОТКАРЛАГЫЧЛЫ** *с.* Тоткарлау җайланмасы булган

**ТОТКАРЛАМА** *и. хәрби* Дошман юлында ясалма киртә, тоткарлык; *русчасы:* **заграждение**. *Мина тоткарламасы. Тоткарлама кору*

**ТОТКАРЛАНУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тоткарлау**. *Милиция тарафыннан тоткарланган кешеләрне тоту бүлмәләрендә бер ай эчендә камералар урнаштырылырга тиеш.* Ватаным Татарстан

2) Эш-хәрәкәт, үсеш акрынлану яисә тукталып калу. *Миңнулла алар янында тоткарланып торырга теләмәде.* В.Нуруллин. *Әгәр дә измә килү тоткарланмаса, әгәр дә балта осталары һәм электриклар белән тарткалашып, юкка вакыт уздырырга туры килмәсә, ун көндә бетерербез.* Р.Вәлиев

3) Кайда да булса берәр эш-шөгыль белән озаграк булу; кирәгеннән артык мавыгу. *Бу юлы инде абориганнәр янында без артык озак тоткарланмадык.* Р.Мөхәммәдиев. *– Мәскәүдә еш буласыңмы? – Узып киткәлибез. Бу юлы бераз тоткарландым.* Р.Кәрами

4) Кичегү, соңга калу, соңару. *Тик кайчакта поездлар гына тоткарлана.* М.Җәлил. *Кассада билет саткан кыз: «[автобус] Соңга калганда да, гадәттә, ярты-бер сәгатьтән артык тоткарланмыйлар», – дигән иде.* Сөембикә

5) Вакытлыча кулга алыну, сак астына алыну. *Әгәр кыйнаучылар җинаять урынында тотылмаган, тоткарланмаган булса, хәзер, инде өч көн вакыт үткәннән соң, ни дә булса ачыклый алырлармы икән?* Н.Акмал. *Вакыйга булган урынга тикшерү төркеме чакырыла, һәм тоткарланган җинаятьчене милициянең дежур бүлегенә озаталар...* М.Насыйбуллин

6) *махс.* Тынычсызлаучының озак тәэсир итүе сәбәпле, организмда тукыма ярсынуы кимү яки бөтенләй тукталу. *Баш миенең зур ярымшарлары сүрүендә ярсыну һәм тоткарлану*

**Тоткарлана бару** Берсе артыннан берсе, булган берсе тоткарлану

**Тоткарлана башлау** Тоткарлану очраклары кабатлану; тоткарлану билгеләре күренү. *--- соңгы елларны бригадирлык йөген бик тырышып тартканга, --- Зөһрә эштә еш тоткарлана башлады.* Р.Кәрами. *Ягулыкка бәя күтәрелү халыкның кесәсенә дә сукты, фаразланган инфляция дә артып китте, хуҗалыкның кайбер тармакларында җитештерү үсеше дә тоткарлана башлады.* Татарстан яшьләре

**Тоткарланып калу** Нииндидер вакыйгадан соң тоткарлану. *Әмма ярты сүзе авызы эчендә тоткарланып калды.* Ф.Яхин. *Татар халкы минем җырларымны кабул итмәсә, бәлки, мин сәхнәдә тоткарланып кала да алмаган булыр идем.* Кәеф ничек?

**Тоткарланып килү** Электән үк, күптәннән тоткарлану. *Әмма икътисади кризиска сылтап, бу мөһим чараны тормышка ашыру гел тоткарланып килә.* Ватаным Татарстан. «*Русия Федерациясенең даими вакытка кучүе турында»гы закон проектын карау, аңлашылмый торган сәбәпләр белән, һаман саен тоткарланып килә.* Татарстан яшьләре

**Тоткарланып тору** Даими яки әледән-әле тоткарлану; билгеле бер вакытка тоткарлану. *Сафа белән Саҗидә, Әкрәм карилар ишегалдында тоткарланып торган булып, иң азактан диярлек чыктылар.* М.Галәү. *Караш күкрәк турысында озак кына тоткарланып торды.* Р.Батулла

**ТОТКАРЛАНУ** II *и.* 1) Организмда барган физиологик процессларның тукталу яки тизлеген югалту күренеше. *Тоткарлану үзәкләре*

2) Үсеш акрынлану яисә туктап калу күренеше. *Яр Чаллыда яшәүче Эллина Мамедова – тумыштан җитди авырулы*

*(психик үсеш һәм сөйләм теле тоткарлануның авыр формасы, симптомлы эпилепсия һ.б.) дүрт яшьлек кыз.* Идел. *Йод җитмәү сәбәпле, акыл үсешенең тоткарлануы күзәтелә.* Мәдәни җомга

3) Вакытлыча кулга алыну, арест. *Полиция митинг узган бина тирәсендә махсус машиналар, автобуслар белән әзерләнеп торса да, тоткарланулар, провокацияләр турында мәгълүмат ишетелмәде.* Кәеф ничек?

**ТОТКАРЛАНУСЫЗ** *с. к.* **тоткарсыз**

**ТОТКАРЛАНУЧАН** *с.* Тоткарлана торган гадәте булган, еш кына тоткарлана торган. *Фәрзәнәнең «хәзер кайтам» дигәне кичкә хәтле сузыла инде ул, аның тоткарланучан гадәте мәңге бетмәячәк.* Йолдыз

**ТОТКАРЛАНУЧЫ** *и. махс.* Сак астына алынган кеше. *Шолохов сүзләренчә, Русиядә полиция бүлегендә тоткарланучының үлү очраклары әледәнәле булып тора.* Ватаным Татарстан. *Тоткарланучының гаражында шулай ук винтовка һәм шактый гына патроннар да табылган.* Татарстан яшьләре

**ТОТКАРЛАНЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тоткарлану**. *Татарстанда соңгы ике елда гына да 1,5 тонна наркотик тоткарланылып юк ителгән.* Шәһри Казан

2) Үзеннән-үзе, үзлегеннән тоткарлану. *Үзәк нерв системасының ярсынуы һәм тоткарланылуы*

3) *з.-сыз* Тоткарланырга туры килү, мәҗбүр булу. *Юлга чыкканда, азрак тоткарланылды*

**ТОТКАРЛАНЫШ** *и. к.* **тоткарлык**

**ТОТКАРЛА́У** *ф.* 1) Эш-хәрәкәтнең башкарылуына яки үсешенә комачаулау, аны сүлпәнләндерү, акрынайту, вакытлыча туктату. --- *кунак безне: «Сезгә хәзер Кыргызстан тау-далаларында гына үскән шифалы үләннәрдән үзем генә белгән рецепт белән чәй эчерәм», – дип тоткарлады.* М.Хәбибуллин. *Билгеле, улыннан хәбәр китергән бу егетне аның үз янында озаграк тоткарлыйсы, улы турында сораштырасы киләдер.* Р.Кәрами

2) *махс.* Тоткарлану (*5 мәгъ.*) барлыкка китерү. *Баш мие һәм арка мие органнар эшчәнлеген тоткарлау*

3) *махс.* Вакытлыча кулга алу. *Ирһатны тоткарлап, кизү бүлегенә озаттылар.* Ватаным Татарстан. *Җинаять урынына килеп җиткән полиция хезмәткәрләре җинаятьчене тоткарлап, «үтерү» матдәсе буенча җинаять эше ача.* Безнең гәҗит

**Тоткарлап бару** Берсе артыннан берсен, булган берсен тоткарлау. *Абыйсының «хат-хәбәрең юк» диюеннән Әхмәтхәсәннең дә Гаяз абыйсына язган хатларын органнар тоткарлап барганын чамаларга була.* Сөембикә

**Тоткарлап калу** Тоткарларга өлгерү. *Урмандагы бөтен кара һәм изге рухларны тетрәндергән бер фаҗига аны тагын кырык көнгә тоткарлап калды.* Г.Гыйльманов. *Әмма кайтып җиткәч, аны кертеп җибәреп, бушлат кигәне мине тоткарлап калды.* Ш.Алпар

**Тоткарлап карау** Сынау максаты белән тоткарлау

**Тоткарлап килү** Электән үк, күптәннән тоткарлау. *Укучылар арасында чиксез уңыш казануы Кингның тәнкыйтьчеләр һәм әдәби элита арасында ихтирам яулавын тоткарлап килде.* Гасырлар авазы. *Борынгы шәһәрчекнең Казаннан шактый ерак урнашуы, су юлы белән якын килеп булмау, анда рәтле кунакханәләрнең төзелмәве туристлар китертүне тоткарлап килгән иде.* Казан утлары

**Тоткарлап кую** Көтелмәгәндә тоткарлау

**Тоткарлап тору** Вакытлыча тоткарлау; һәрвакыт, гел яки хәзер, сөйләү моментында тоткарлау. *Кем белә, бәлки, шушы буран вакытлыча безнең һөҗүмне дә тоткарлап тора торгандыр.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин аны монда күңеллелектән башка әле икенче бернәрсә дә тоткарлап тора иде.* Н.Фәттах

**Тоткарлый башлау** Тоткарларга тотыну. *Татарстанда мөфтият җитәкчелегенә һөҗүмнәрдән соң күпләгән мөселманнарны тоткарлый башладылар.* Н.Алан. *Минә ни өчен: шәхес иреген абсолют кыйммәткә әверелдереп, ахирәтне оныту алга таба Көнбатышның үсешен тоткарлый башлады.* Р.Сафин

**Тоткарлый төшү** Тагын да бераз тоткарлау; беркадәр тоткарлау. *Туктаусыз яуган яңгырлар кыр эшләрен тоткарлый төште*

**ТОТКАРЛЫ** *с.* Тоткарлыклар тудыра торган. *Тоткарлы эш. Тоткарлы кеше*

**ТОТКАРЛЫК** *и.* 1) Эш-хәрәкәтнең үтәлешенә комачаулык итә, аны туктата, хәтта юкка чыгара торган сәбәп; комачау, киртә. *Ак патшага каршы адәмнәр белән күп катнашы бар, шундый сүзләре ишетелә дип, монда тоткарлык чыкты.* Г.Ибраһимов. *Станциягә, кассага шалтыратырмын. Билет тоткарлыгы булмас.* Д.Гайнетдинова

2) Җанлы-җансыз нәрсәләрнең юлына төшеп, хәрәкәтләрен уңайсызлый, тоткарлый торган сәбәп; киртә, комачау. – *Ләкин безнең юлыбызда тоткарлык бар, күлне һич кичеп чыгар хәл юк, – диләр.* Әкият. *Сиваш? Перекоп? Хәзерге заман армиясе өчен алар җитди тоткарлык түгел. Фрунзе армиясе үтте, без дә үтәрбез.* И.Гази

3) Каршы тору, каршылык. *Хак булса, күчеп китүчеләргә берничди тоткарлык булмаячак, ди.* М.Галәү. *Әгәр китәбез, үзебезнекеләргә кайтабыз дисез икән, пожалысты, тоткарлык юк, китәсез.* Ә.Еники

4) Төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә эшхәрәкәтнең вакытлыча тукталып торуы. *Әйтик, мин дә вакытында илтеп тапшырмадым, ди, башка колхозлар да илтмәделәр, ди. Шуның аркасында, мин сиңа әйтсәм әйтим, кайбер урыннарда тоткарлык килеп чыгуы бар бит, ә!* Г.Бәширов. *Канаданың Монреаль һәм Оттава аэропортлары эшләүдән туктаган, АКШның өч халыкара аэропортыннан самолётлар берничәшәр сәгать тоткарлык белән очып китә.* Татарстан яшьләре

**ТОТКАРЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **тоткарлау**. *Хөкүмәт күченеп китүчеләргә тоткарлык итмәячәк, дигән озынколак хәбәре, тора-бара, чыннан да, дөрескә чыкты.* М.Галәү. *Тирән кар, урманнар һәм сазлыклар аша юллар булмавы гаскәрләрнең алга барышына тоткарлык итә.* Р.Мостафин. --- *Миңлебайның Гарифҗанга каршы көрәшкә чыгуына алар һич тә тоткарлык итә алмый иде.* Н.Яһудин

**ТОТКАРЛЫКЛЫ** *с. к.* **тоткарлы**

**ТОТКАРЛЫКСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Бер төрле дә комачаулык, тоткарлык күрмичә яисә күрсәтмичә; тоткарламыйча яисә тоткарланмыйча. *Язгы чәчү вакытында кыр станында безнең тракторчыларыбызны һич тоткарлыксыз тәмле-тәмле ашлар пешереп сыйлап торганы өчен, өлкән колхозчыбыз сөекле Мәрвибану апа Хәйретдинова бер күлмәклек штапель белән бүләкләнә ---.* Ф.Хөсни. *Менә безнең кулда барча оккупацияләнгән өлкәләрдә тоткарлыксыз йөрергә мөмкинлек биргән документ.* Х.Камалов

2) Җиңел, бик тиз, уйлап-нитеп тормастан; туктамыйча, тотлыкмыйча. *Нәкый абый яттан һич тоткарлыксыз Сәгыйть Рәми шигырьләрен сөйли башлады ---.* Р.Батулла. *Бала бернинди тоткарлыксыз «Фатиха» сүрәсен яттан укыды.* Ш.Алпар

**2.** *с. мәгъ. к.* **тоткарсыз 2.** (*1 мәгъ.*). *Тоткарлыксыз хәрәкәтне оештыру өчен, тиешле юл билгеләре куелачак*

**ТОТКАРСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Тоткарлыксыз, соңармыйча; тиешле вакытта, кичекмичә. *Бу ссуданы (исем, фамилия) фахишәлек итеп тапкан акчаларыннан, һич тоткарсыз, фәлән срокта түләп бетерергә тиеш.* Г.Кутуй. *Кирәкле белешмәләрне тоткарсыз алдылар.* М.Галәү

2) Берсүзсез; һич бернинди каршылык күрсәтмичә; шунда ук. *Аннан шул көнне үк хәбәр дә килде: «Беренче килгән очкычта, һичбер тоткарсыз, экспедиция башлыгы Оттоны коткарыгыз», – диелгән иде.* А.Алиш. *Мин тоткарсыз җавап биреп утырдым: – Белмим.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Туктаусыз, туктамый торган, даими, өзлексез. *Тоткарсыз бер сагыш кабына, Дөрли сагыш минем күңелдә.* Ф.Кәрим. *Исәнбәт – чынлап та шагыйрь. Аңарда бай хиссиятләр теле, тоткарсыз тойгы, табигый агым бар.* Х.Миңнегулов

2) *к.* **тоткылыксыз**

**ТОТКАРСЫЗЛЫК** *и.* Бер җирдә дә тоткарлыклар булмау; хәрәкәттә, барышта, процесста булу; иреклелек, иркенлек. *Ышанычлылык дүрт сыйфаттан тора: тоткарсызлык, гомер озынлыгы, ремонтка яраклылык, саклanучанлык.* Фән һәм тел

**ТОТКЫ** *и.* 1) *к.* **тотка**. *Гасырлар буена Россия халыкларында, шул исәптән татарларда да, гаиләнең тоткысы рухи кыйммәтләр булган.* Г.Бубый

2) *диал.* Тотрык, тотрыклылык. *[Керенский чорында] сәясәттә тоткы юк.* Х.Кәрим

**ТОТКЫЗУ** *ф. диал. к.* **тоттыру**. *Дүрт пәрине култыгыннан тоткызып, Төште Иблис җиргә.* Ш.Бабич

**ТОТКЫЛЫКСЫЗ** *с.* Бәвелен тота алмый торган. *Тоткылыксыз бала*

**ТОТКЫН** *и.* 1) Сугышта дошман, каршы як кулына эләккән кеше, әсир. *Тоткын итеп сиңа китерде дә Кол дип мине немец атады.* М.Җәлил. *Шул ук Алмазда хәзерге моментта нәкъ менә минем белән сезнең шикелле үк совет яклы йөзләп кеше аклар кулында тоткында ята.* В.Нуруллин. *Ә немецлар өчен сарайда яткан хәлсез ике тоткын артык йөк иде бугай.* М.Галиев

2) *к.* **тоткынлык**. *– Әйдә әле, менә алар бу бүлмәдә биш-алты елдан бирле тоткында утыралар, – дип әйтте дә, ди, күрше бүлмәдән ике апасын алып чыкты, ди.* Әкият. *Без инде һәрберебез елдан артык тоткында: гаиләдән аерылган.* И.Салахов. *Шушы язуны алу белән үк, аннан гафу үтен һәм аны тоткыннан азат ит!* В.Нуруллин

3) Гомумән ирек чикләнгәнлек. *Океан – дөнья йөзендәге иң зур төрмә ул, ялгызак төрмәсе, мин ирекле баштан шуның тоткыны идем һәм тәүлегенә унбишәр сәгать ишәргә мәҗбүр ителдем.* А.Гыйләҗев

4) Ирегеннән мәхрүм ителеп төрмәгә ябылган, сак астына алынган кеше; мәхбүс. *Муса әфәнде төрмәгә ябылганның икенче көнендә --- Габденнәсыйр әфәнде һәм господин Андреев, тоткын Мусаның хәлен белер өчен төрмәгә килеп, төрмә башлыгының рөхсәте белән, Муса әфәнде ябылган камерага керделәр.* З.Бигиев. *Моны ишеткәч, тоткынның күзләре очкынланды, йөзе нурланды ---.* Р.Кәрами

5) Читлектәге кош яки хайван. *Сандугачны тоткын иткәннәр, Читлек эченә ябып куйганнар да, Сайрасын, дип боерык биргәннәр.* А.Алиш. *Шулчак тоткын бүре кинәт ыргылып, арттан камаучы эт өеренә ташланды ---.* Р.Батулла

6) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөкиббән киткән, аның белән саташкан кеше. *Ханым киреләнмәде ---. Тавышы тагын да ямьләнеп китте. Хәбирнең күңеле серле бер богау белән аның тоткынына әверелә барды.* Ф.Яхин

**ТОТКЫН ИТҮ** *ф.* 1) Әсир итү. *Пиратлар иллегә якын кешене тоткын итеп, үзләренә эшләтеп яткыралар.* И.Хуҗин

2) Сак астына алу, ябып кую. *Әгәр ул тоткын ителә икән, димәк, Хәдичә туташ һәм йөз мең сум көмеш акча Габденнәсыйр әфәнденеке булачак.* З.Бигиев. *[Клара:] Сине тоткын итәргә, шулай итеп әниеңнең эзенә төшәргә уйлыйлар икән.* А.Алиш.

3) Тоткарлау, нәрсәне дә булса эшләргә ирек, мөмкинлек бирмәү

4) *күч.* Кемне дә булса сокландыру, аның игътибарын җәлеп итү, күңелен яулау. *Күр, ничек күкләрне, егетем, балкытадыр йөзләрең, Аһ, мине тоткын итә, егетем, сихерле күзләрең.* Ф.Бурнаш. *Соңгы әйтелгән сүзе тылсымлы иде. Туң йөрәкләр дә шушы сүздән эреп китәләр. Санияне дә тоткын итте бу «бәгырем» дигәне.* Ф.Яхин

**ТОТКЫНЛЫК** *и.* 1) Сак астында, төрмәдә, ябылуда булу; тоткын булу хәле. *Ил бәйрәмен инде өченче кат Тоткынлыкта, читтә үткәрәм.* А.Алиш. *Сугышта плен төшеп яки тоткынлыктан качып, төрлесе төрле якларга таралган якташларыбызны уйлап утырдым.* Р.Кәрами. *Казан алынган 1552 елның октябрендә Сөембикә Касыйм каласында тоткынлыкта була.* Ф.Урманчеев

2) Гомумән әсирлек. *Бары бу комедияне уйнап бетерәсе бар да шушы бинада тоткынлыкта озын һәм күңелсез бер төн уздырасы гына бар...* М.Галәү. *Совет кешеләре боз тоткынлыгында искиткеч нык тордылар.* А.Алиш // Ябылып тору. *Чыгарга өлгермәгән маллар – өч бозау белән аягы имгәнгән кәҗә тоткынлыкта калды.* Р.Батулла. *Ә тоткынлыкта тигрлар гадәттә 10 елдан артык яшәми икән.* Биология

3) *күч.* Ирексезлек, бәйлелек, коллык. *Тоткынлыкта, күкрәк читлегендә Бәргәләнеп сула шигырь-кош.* С.Әхмәтҗанова. *Кол булдык без шуннан бирле, Илебез – тоткынлык иле.* Р.Нуруллин

**ТОТКЫННА́Р ЙОРТЫ** *и.* Төрмә, зиндан. *Ул, тоткыннар йорты алдындагы сакчыларга кырыйлатып күз төшергән хәлдә, мәйданчыкны үтеп, сулга борылды.* Ш.Камал

**ТОТКЫР** *и. к.* **тоткар**

**ТОТКЫЧ** *и.* 1) *к.* **тотка** (*1–3 мәгъ.*). *Ул, тулып ташкан күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, хәлсез куллары белән ишек тоткычын кармалады...* Ф.Садриев. *Семёнов кайдандыр бер лезвие кисәге юнәткән. Аны тимерчыбыктан ясалган тоткычка җайлап куйган.* Казан утлары

2) Берәр нәрсәне төшерми, ычкындырмый тотып торыр өчен кулланыла торган җайланма. *Инструментлар шкафында көмештәй ялтырап --- бәләкәй пычкылар, инә тоткычлар [ята].* Г.Минский. *Тукымадан энә куйгыч, кайнар әйбер тоткыч тегеп куйсаң да күңелле булачак.* Йорт эшләре

3) *иск.* Китапның кирәкле битенә кыстырып куелган тар, төрле төстәге кәгазь кисәге. *Син миңа 86 җилдле урыс китапларының тоткыч (кәгазь билге) салынганнарын китер.* Ф.Әмирхан. *--- ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.* Ә.Еники

**ТОТЛЫГУ** *ф.* 1) Сөйләгәндә, кайбер авазларны авырлык белән әйтү, ихтыярсыздан бер үк авазларны кабатлау. *– Га-га-гали-җәнап-п, – дип тотлыкты Исмәгыйль.* С.Зыялы

2) Курку, оялу һ.б. нәтиҗәсендә, сөйләгәндә, сүзләрне бик авырлык белән табу, тукталышлар ясау, сөйли алмау. *Трубкада ашыгудан тотлыга-тотлыга сөйләгән хатын-кыз тавышы ишетелде.* Р.Кәрами. *Дилә куркудан тын да ала алмый торды: – У-л-лым, – диде тотлыгып, – ни булды?* З.Кадыйрова // Бәйләнү, әйләнмәү (тел тур.). *Шәйхи картның шунда егәре китеп, теле тотлыкты.* М.Мәһдиев. *Теле тотлыкты, бәйсез һәм җиңел генә әйтеп салырга теләгәне килеп чыкмады.* Ф.Латыйфи

3) *диал. к.* **тотылу** (*4 мәгъ.*). *Ай тотлыгу*

**Тотлыга башлау** Тотлыгырга тотыну. *Башыма да китермәгән идем мондый холыклы кеше дип. Аптырап калдым, тотлыга башладым.* Ф.Баттал. *– Мин... мин, – Ардалион тотлыга башлады, чак кына күзлеге төшеп китмәде, тотып калды.* И.Салахов. *Шулай диденңме, гарьлектән, Вакыйфның теле тотлыга башлый, күзенә яшь тула.* Р.Мөхәммәдиев

**Тотлыга төшү** Бераз, беркадәр тотлыгу. *– Тик менә, – диде ул, ниһаять, шул уен әйтергә сүзләр эзләгән кебек, тотлыга төшеп, – шуны, ничек дим, сез әйткәнчә, дөреслекнең шифалы булуын димме.* Ә.Еники. *Егет, гадәтенчә бераз тотлыга төшеп, әйтеп куйды ---.* Ә.Дусайлы

**Тотлыгып алу** Аз гына, кыска вакытка тотлыгу. *Безнең түрә каушап, тотлыгып алды.* И.Салахов. *Әллә каушадым, әллә башка сәбәптән, моңарчы күрелмәгән хәл: телем тотлыгып алды.* Ф.Яхин

**Тотлыгып калу** Нинди дә булса вакыйгадан соң кинәт тотлыгу. *Рәдиф беркавымга тотлыгып калды.* В.Нуруллин. *Мәдинә үзе белән килеп исәнләшүчене кем дип дәшәргә дә белмичә тотлыгып калды.* М.Хәсәнов. *Шәмгун кинәт кенә тотлыгып калды, аскы иреннәрен тешләп, кулындагы тәмәке төпчегенә текәлеп торды.* Ф.Шәфигуллин

**Тотлыгып кую** Кинәт тотлыгу; бер тапкыр тотлыгу

**Тотлыгып тору** Бераз вакыт тотлыгу. *Гомер буе көткән кешесе белән гел уйламаган чакта очрашкан гашыйклар гына шулай югалып кала торгандыр, башка һични әйтә алмый тотлыгып торды профсоюз активисты ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Кем икәнен күргәч, ачуланырга әзерләнгән авызы, елмаюга күчә алмыйча, тотлыгып торды.* Р.Вәлиев. *Трубканың икенче башындагы кыз, нәрсә әйтергә белмәгәндәй, тотлыгып торды.* Х.Ширмән

**ТОТЛЫКЛЫ** *с. сир.* **1.** Тотлыга торган, тотлыгучан

**2.** *рәв. мәгъ.* Тотлыгып, туктап. *Юан, чыршайган битле карт бер карчык тотлыклы, сикәлтмәле чыккан тавыш белән [әйтте].* М.Гафури

**ТОТЛЫКСЫЗ** *рәв.* 1) Тотлыкмыйча, туктаусыз. *«Шәһри Чаллы»ның бүгенге көндә һич тотлыксыз әйтерлек нибары бер штаттан тыш хәбәрчесе бар, ул да булса – Җәүдәт Харисов.* З.Мифтахов. *Тотлыксыз сөйләү*

2) Өзлексез, бер дә туктамый. *Бер тотлыксыз йөрү*

**ТОТЛЫКТЫРУ** *ф. з.-сыз* Тотлыгырга туры килү

**ТОТМА** *и. диал.* Бер учка сыйган кадәр әйбер, учма. *Мин, утырган килеш, атлар тотам, ә абый чабу машинасыннан тотмалар төшерә.* Ш.Камал

**ТОТНАК** *и.* 1) Үз-үзеңне тота белү, үз-үзеңне нык тоту; эчке дисциплина; рухи культура. *Телгә алай бик тотнагы булмаган бер кияү әзрәк салып килгән иде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Тотнагың бүтән [синең]. Җаның сабыр.* Казан утлары

2) *диал. к.* **тотрык** (*1 мәгъ.*). *Читләрендәге сызыклар, үземчә, камышлар, ә уртадагы алсу түгәрәк, үземчә, кояшның – галәмебезнең тотнагы булган кояшыбызның – күлдә чагылышы.* М.Хуҗин. *Картайгач тотнак булмау*

3) *к.* **тотрык** (*3 мәгъ.*). *Дөньяның тоткасы да тимер казык белән бәйле икән. Элегрәк авыл җиренең бар тотнагы да шул казыкта булган дип уйлыйм мин.* Г.Нурулла

**ТОТНАКЛАНУ** *ф.* Тотнаклыга әйләнү; тотнаклы булып китү

**Тотнаклана бару** Торган саен күбрәк тотнаклану. *Фестиваль елдан-ел җисеме һәм исеме таләпләренә туры килгән рәвештә тыйнаклана, тотнаклана бара.* Мәдәни җомга

**Тотнаклана башлау** Тотнаклану билгеләре сизелү

**Тотнаклана төшү** Бераз, беркадәр тотнаклану

**Тотнакланып китү** Ниндидер сәбәп аркасында кинәттән тотнаклану

**ТОТНАКЛЫ** *с.* **1.** 1) Үз-үзен тиешенчә тота белә торган, сабыр; тыйнак, әдәпле; эчке дисциплинасы булган. *Ләкин гадәттә ифрат тотнаклы,*

*оялчан Ленизага ни булган әле бүген?* М.Маликова. *Әнисе аңлар: Алсу – тыйнак, тотнаклы кыз, кирәк-кирәкмәс адымга бармас.* Э.Закирова

2) Тоткан юлында нык, эзлекле, турылыклы. *Болар – коммунист әдипләрнең тотнаклы, хәзерлекле һәм шуның өстенә әдәби җитеш булганнары.* Г.Нигъмәти. *Политик яктан яхшы әзерлекле, идеологик яктан тотнаклы, Ленин партиясе эшенә тугрылыклы.* М.Җәлил

3) *диал. к.* **тотрыклы** (*3 мәгъ.*). *Сәхнә теленең беренче дәресләреннән үк, мин студентларымның бер-берсенә әдәпле, игътибарлы булып, тотнаклы мөнәсәбәтләр урнаштырып эшләүләрен күзәтәм ---.* Сәхнә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әдәпле, тыйнак рәвештә. *Нәфисә сүз барышында кулын кискен, ләкин тотнаклы бер тилпендереп, чәч толымын артка чөя.* Г.Бәширов. *Язу эшләре, бер-икесеннән башкасы, ы-ы... тотнаклы язылганнар.* А.Әхмәт

2) Эзлекле рәвештә, билгеле бер эзлеклелек белән. *Татар үзенең татарлыгын авылларда гына тотнаклы хәлдә саклап килә.* Ш.Алпар. *Совет үзенең һәрбер әйберен яхшы, тотнаклы итеп эшләргә тырыша.* Атака

**ТОТНАКЛЫЛЫК** *и.* 1) Үз-үзеңне тота белү, сабырлык; тыйнаклык, әдәплелек. *Доцентның тотнаклылыгы, үзенә шулай әйбәт мөнәсәбәттә булуы --- Мәдинәне тәмам әсир итте.* А.Расих. *Фәкать аның өчен зур иман, зур иҗтиһад вә һичбер каршылыктан курыкмас бик нык бер тотнаклылык кирәк.* Г.Бубый

2) Тотнаклы булу; ныклык, тотрыклылык, турылыклылык. *Хисләр сафлыгы, җир кызын күкләргә күтәрү, аңа нечкә мөнәсәбәт, бу мөнәсәбәтнең аерылганнан соң да саклануы, трагик хәлләрне кичерүдә тотнаклылык, мәхәббәттә тыйнаклык милли эстетик идеал белән дә нигезләнә.* Р.Рахман. *Хәзер аңлыйм: безнең күпчелегебезгә хас тотнаклылык, басынкылык, уйлап эш итүчәнлек, сөйләшеп килешә белү, сүз куеша белү, конфликтларны җайлап, кешеләр арасында татулык урнаштыра алу сәләтен кайберәүләр хәйләкәрлек дип аңлый булса кирәк.* Мәдәни җомга

**ТОТНАКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Үз-үзен тота алмый торган, сабырсыз, инсафсыз; тыйнаксыз, әдәпсез. *Я, сиңа әйтәләр бит инде, тик утыр, дип, бу кадәр тотнаксыз бортак авыз булырсың икән!* Г.Камал. *Әйе, җиңел булмагандыр аңа әлеге сүзләрне ишетү. Әгәр үзе тотнаксыз хатын булып, койрык болгарга яратса, бәлки, исе дә китмәс иде.* Р.Кәрами. *Хәер, ул бит тотнаксыз егет түгел, тик үзенең кызны бик нык сөйгән яры итәсе килә иде.* Р.Гаязетдин

2) Тоткан юлында, эшендә, уенда аумакай, эзлексез, тотрыксыз, мәсләксез. *Политик тотнаксыз һәм художество ягыннан сай булган либреттоларны үткәрмәү миңа бик кыенлык һәм көрәш аркылы гына насыйп булды.* Җ.Юныс

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әдәпсез рәвештә

2) Эзлексез, таркау рәвештә. *Шушы әсәрләр рәтеннән, комсомол типларны артык бозып, тотнаксыз төстә биргән әсәрләр дә күп кенә очрый.* М.Җәлил. *Тотнаксыз эш итү*

3) Тыелгысыз, тыела алмыйча. *Сәлимә гасаби һәм тотнаксыз рәвештә елап җибәрде.* Ф.Әмирхан

**ТОТНАКСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Тотнаксыз булып китү; холыксызлану. *Белмәссең, үзен солдат өчен якын итеп күрсәтергә тырышуымы, әллә үтә ялагайлыгына бирелеп тотнаксызлануымы – хәтта ары-бире йөрештереп алды.* С.Шәрипов. *Кәбир хатынның битеннән үбеп алды. Аннары, тәмам тотнаксызланып, кочагына ук кысты.* С.Мәхмүди. *Әле кичәле-бүгенле өйләнгән кешегә тотнаксызланырга ярамый.* Совет әдәбияты

2) Тотнаксызлык күрсәтү. *Нигә болай тотнаксызланып йөрисең?*

**Тотнаксызлана бару** Торган саен күбрәк тотнаксызлану. *Ул елдан-ел тотнаксызлана, түземсезгә әйләнә барды.* Р.Мирхәйдәров

**Тотнаксызлана башлау** Тотнаксызлану билгеләре сизелү

**Тотнаксызлана төшү** Аз гына, бераз тотнаксызлану

**Тотнаксызланып бетү** Тәмам, бөтенләй тотнаксызлану

**Тотнаксызланып китү** Ниндидер сәбәп аркасында кинәттән тотнаксызлану

**ТОТНАКСЫЗЛЫК** *и.* 1) Үз-үзен тиешенчә тота белмәү, сабырсызлык, түземсезлек. *Хәл кылынып бетмәгән мәсьәлә турында шалтырап начар иткәнсез, иптәш Дубцова. Тотнаксызлык һәрвакыт эшкә зарар китерә.* Ш.Камал. *Юлда ирләрнең тотнаксызлыгына беренче тапкыр гына юлыкмаганга тулгандыр инде күңеле, дидем мин.* Шәһри Казан

2) Тыйнаксызлык, әдәпсезлек, инсафсызлык. *[Шамилне] мораль тотнаксызлыкта гаеплиләр. Хатын-кызлар белән күңеле чиста түгел, диләр.* А.Гыйләҗев. *Миләүшәгә булган хисләренең Мәрзыя фикерендә, таныш-белешләр күзендә, хәтта әнисе уенда да тотнаксызлык булып саналасын төшенә иде.* Д.Гайнетдинова

**ТОТРЫК** *и.* 1) Селкенмичә, аумыйча, тирбәлмичә яисә җимерелмичә тору сыйфаты; ныклык. *[Күрше] шактый ук төшереп өлгергән, шулай да аягының тотрыгы китмәгән иде әле.* Б.Камалов. *Сыер муенына бәйләгән кытыршы сүс арканның бер очын Миннәт кулына чорнаган, хайван тотрыгын югалтып авыш-тәвеш таудан кызулый башлауга, ул, кыска һәм юантык аякларын тери-тери, бөтен гәүдәсе белән артка каерыла ---.* А.Вергазов

2) Үз-үзен тота алу, ныклык, сабырлык. *Аннары гына аңыма килеп, дөресрәге, соңгы тотрыгымны да югалтып, шашынып, әни кроватена ташландым.* М.Шабай. *Ул егетне куенына салырга ашыкмый, Гыйльменисаның ул яктан тотрыгы җитә.* Ф.Хөсни

3) Үзгәрешсез булу, даими булу, даимилек, стабильлек. *Тарихка ул --- 1996 елның ахырында тотрыгы какшаган җәмгыятебезне кискен үзгәреш, җимергеч борылышлардан саклап калучы кеше буларак та керәчәк.* Я.Шәфыйков. *Һава торышының тотрыгы булмау*

4) Эзлеклелек, мантыйк. *Бабай сүзенең тотрыгы юк*

5) *диал.* Ике казык арасы, ике терәк арасы, торык. *Өчәүләп, бер тотрык озынлыктагы бу читәнне урыныннан*

*җай гына каерып алып, уң якка борып куйдылар.* Г.Галиев

6) Ярдәм, терәк, таяныч. *Тотрык бирү*

**ТОТРЫКЛАНДЫРГЫЧ** *и. к.* **стабилизатор**. *Майонез сыек булса, төрле тотрыкландыргыч матдәләр кушалар*

**ТОТРЫКЛАНУ** *ф. ялг. к.* **тотрыклылану**. *Йөрәк яхшы эшли башлый, кан кислородка байый, канда холестерин түбәнәя, йокы яхшыра, канда шикәр күләме тотрыклана ---.* Сәламәт булыйк! *Бурдин фикеренчә, фәнни фразеологизмнар кайчак терминнар сыйфатында тотрыклана.* Остаз кадерен оста белер

**Тотрыклана бару** Акрынлап тотрыклану. *Татарстан икътисады әкренләп тотрыклана бара.* Сөембикә

**Тотрыклана башлау** Тотрыклану билгеләре сизелү. *Соңгы араларда Казан клубыннан килеп ирешкән хәбәрләр, чыннан да, «Рубин»да хәлләрнең тотрыклана башлавына ишарәли.* Шәһри Казан. *Фаразларга ышансак, август аенда күчемсез милеккә бәя тотрыклана башлый.* Ватаным Татарстан. *Баксаң, илнең кризис аркасында эштән чыккан икътисады рәткә керә, тотрыклана башлаган, бюджет кытлыгы кимегән икән.* Татарстан яшьләре

**Тотрыклана төшү** Аз гына, бераз тотрыклану. *--- демографик хәлнең бераз тотрыклана төшүе төбәкне башка субъектлар арасында берникадәр күтәрде.* Фән һәм тел

**ТОТРЫКЛЫ** *с.* **1.** 1) Селкенмичә, тирбәлмичә, аумыйча тора алган, тотрыгы, тиешенчә ныклыгы булган. *Җир шарындагы зур тигезлекләр Җир кабыгының чагыштырмача тотрыклы участокларына – платформаларга, ә җыерчыклы биек таулар системасы сейсмик поясларга – литосфера плитасының кырыйларына туры килә.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Батынкы урында тотрыклы тигезләнеш хәлендә торучы шарчыкның авырлык үзәге теләсә кайсы янәшә торыштагыдан түбәнрәк була.* Физика

2) Йомшап, чәчелеп, уалып тормаган, нык. *Болай эшләгәндә, ашаган чакта бәлештән кәбестә коелмый, эче тотрыклы була.* Халык ашлары

3) Теләсә нинди шартларда да үзгәрмәүчән, бернинди дә тәэсиргә бирешмәүчән; ныклы, даими. *Аннары мин Кытай-Чин дәүләтенең канун-карарлары тотрыклы, үзгәртүләргә бирешми торган итеп, бик нечкә язылганлыгы хакында белдем.* М.Галиев. *Урта хәлле, уртадан югарырак булып, аякларында нык басып торган байлар Җаек сәүдәсенең тотрыклы керемен бирүчеләр катлавын барлыкка китергән.* Р.Батулла

4) Үз сыйфатларын югалтмаска, озак сакланырга сәләтле. *Тотрыклы химик матдә*

5) *күч.* Үз карашларына нык инанган; эзлекле, ышанычлы. *Шулай да Латышев бик үк тотрыклы кеше булмаса кирәк, диде.* Х.Камалов. *Ир белән бергә һәм ир кеше канаты астында булганга гына, азмы-күпме тотрыклы кеше.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Селкенмичә, аумыйча, җимерелмичә. *[Мәдинәнең] йорты таркалмый, шактый тотрыклы күренә. Хәтта чак-чак кына ныгу галәмәтләре дә күзгә бәрелә.* Ш.Камал

2) Инсафлы, әдәпле итеп. *Ул һәрвакыт тотрыклы булырга тырыша*

**ТОТРЫКЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Тотрыклы хәлгә килү, нык тора алу; тотрыклы булып китү. *Гәүдә тотрыклылану*

2) Нормаль хәлгә килү, стабильләшү. *Республика туберкулёз авыруына каршы клиник диспансер директоры Равил Вәлиев әйтүенчә, соңгы өч елда хәл тотрыклылана ---.* Ватаным Татарстан. *Шәһәргә шунда ук гаскәр кертелә, һәм, әйтүләренчә, корбаннар хисабына хәл тотрыклылана.* Татарстан яшьләре

**Тотрыклылана бару** Акрынлап тотрыклылану. *Иҗади яктан үсә һәм карашлары тотрыклылана барган саен, Җәлил дингә һөҗүмен туктатып кына калмый, бәлки бу өлкәдә арттырып җибәрүләргә каршы чыга башлый.* Р.Мостафин. *Генерал республикадагы хәлнең тотрыклылана баруын сөйләде.* Ватаным Татарстан

**Тотрыклылана башлау** Тотрыклылану билгеләре сизелү

**Тотрыклылана төшү** Бераз тотрыклылану. *Аның сүзләренчә, җәяүлеләр өчен каралган юл кичүләрендә кеше бәрдерүләр буенча вазгыять тотрыклылана төшсә дә, --- зур шәһәрләрдә бу мәсьәлә актуальлеген югалтмый, хәл катлаулы кала.* Асылъяр

**Тотрыклыланып җитү** Тәмам, тулысынча тотрыклылану

**Тотрыклыланып калу** Билгеле бер хәл-сәбәптән соң тотрыклылану. *Аннары килеп, хезмәт хакы түләү шартлары да колхозчылар файдасына авышып һәм тотрыклыланып калгач, колхоз эшеннән читләшеп йөрүчеләр дә эшне үзләре сорап алып эшли башладылар.* В.Нуруллин

**Тотрыклыланып килү** Акрынлап тотрыклылану. *Хәзер вазгыять акрынлап тотрыклыланып килә*

**Тотрыклыланып китү** Нинди дә булса сәбәптән яки билгеле бер вакыттан соң тотрыклылану. *Һава торышының тотрыклыланып китүен бик теләр идек.* Мәдәни җомга

**ТОТРЫКЛЫЛЫК** *и.* 1) Тотрыклы (*1, 2 мәгъ.*) булу үзлеге

2) Ныклык, эзлеклелек. *Бу нәселгә тотрыклылык хас, һәм ул дәүләтнең куәте бик нык үскән дәвердә идарә иткән.* Р.Фәхретдинов. *Яшьләрдә тотрыклылык азрак, тамыр җибәреп өлгермәгән.* Ш.Галиев. *Саматта – авыл егетендә – тырышлык, даимилек, эш-планнарда тотрыклылык көчле.* М.Вәлиев

3) Даимилек, үзгәрмәүчәнлек. *Безнең илдә тотрыклылык мәңге булмаячак.* Х.Ширмән. *Фразеологик берәмлекләр составларының тотрыклылыгы, сүз тәртибенең ныклы булуы белән аерылып торалар.* Казан утлары

**ТОТРЫКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тотрыгы, ныклыгы булмаган; какшый, калтырый, селкенә, авыша, ава торган. *Иптәшләр! Моңа баса күрмәгез. Тотрыксыз баскыч бу.* К.Нәҗми. *Тотрыксыз тизләнеш. Тотрыксыз корылма*

2) Йомшак, чәчелеп китүчән, уалучан. *Тотрыксыз туфрак*

3) Хәлсез, ышанычсыз. *[Айтуган карт] тотрыксыз тезләре белән картларча уңайсыз атл[ый].* Г.Бәширов. *Табиб, аның --- куллары да калтырый, гәүдәсе тотрыксыз, сөйләме дә бәйсез, диде.* Сөембикә

4) *физ., хим.* Алмашынучан, үзгәреп торучан; бүтәнгә әверелүчән. *Аның халәте тотрыксыз һава торышы кук.* З.Мәхмүди. *Өй алдында кар тотрыксыз ---.* Н.Абдулкәримова. *Аларның болай да бизмәндәге сыман чайкалган, кинәт кенә астыртын шатырдаган язгы боздай тотрыксыз тормышлары җилдә биегән шәм ялкыны сыман --- чайкала башлады...* Идел. *Тотрыксыз төшләр*

5) Даими булмаган, эзлексез, үзгәрүчән. *Әдәп-тәртип чылбыры тотрыксыз бит ул.* Х.Камалов. *Ә сәясәт, белгәнебезчә, бик тә тотрыксыз нәрсә.* Р.Вәлиев. *Чөнки аның күңеле, тәмам изаланып, тотрыксыз, ният-карарсыз бер хәлгә төшкән иде...* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Үз карашларында эзлексез, ышанычсыз; аумакай. *Шулар арасыннан үз фикере булмаган, тотрыксыз, һәрнәрсәгә тиз ышанучан, ни кушсаң, шуны үтәргә риза булган кешеләрне эзләп таба.* Р.Гарифуллин. *Мондый башбаштаклык, билгеле ки, офицер тарафыннан кичерелми: ул «хәрби дисциплинага буйсынмый торган тотрыксыз солдат»ны полктан кудыруга ирешә.* Җ.Юныс

**2.** *рәв. мәгъ.* Ышанычсыз итеп; хәлсез, дерелдәтеп. *Шәвәли абзый бүрек кигән, бөкрәйгән: аякларын, ничектер, тотрыксыз китереп баса.* Г.Ахунов. *Бүген без ул нигез ташын суырып алып, аны тотрыксыз рәвештә, бер аягына бастырып калдырдык.* Ш.Алпар. *Бу уңайдан мобиль, махсус рәвештә тотрыксыз итеп ясалган декорацияләр һәм көлкеле пластик миниатюраларны аерым билгеләп үтергә кирәк.* Сәхнә

**ТОТРЫКСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* Тотрыгын алу, тотрыктан мәхрүм итү, тотрыксыз итү, тотрыксызга әйләндерү. *Хәмзин бу төркемнәрне Кырымдагы вазгыятьне тотрыксызландырып, Грузиянең Көньяк Осетия төбәгендәге кебек хәл чыгарырга маташуда гаепләде.* Н.Акмал. *«Рөхсәтсез миграциягә каршы» хәрәкәтенең Татарстанга үтеп керүе хәлне тотрыксызландыра.* Л.Харрасова

**Тотрыксызландыра бару** Акрынлап тотрыксызландыру

**Тотрыксызландыра төшү** Бераз тотрыксызландыру; тагын да тотрыксызландыру

**Тотрыксызландырып тору** Даими, һәрвакыт яки әледән-әле, еш тотрыксызландыру

**ТОТРЫКСЫЗЛАНУ** *ф.* Тотрыксыз булып китү, тотрыксызга әверелү; йомшау. *[Әпипә], --- бөтен гәүдәсе тотрыксызланып, баскан урынында лып итеп җиргә утырды.* Г.Бәширов. *Эрегән тимер катламы тотрыксызлана һәм түбән төшә, җиңелрәк матдәләр өскә күтәрелеп, каты мантия хасил итәләр.* Фән һәм тел

**Тотрыксызлана бару** Акрынлап тотрыксызлану. *Халкыбызның үз-үзен саклау иммунитеты тотрыксызлана бара.* Р.Вәлиев

**Тотрыксызлана башлау** Тотрыксызлануга табан үзгәртү. *Бухаров белән Семак киткәч, «Рубин» тотрыксызлана башлады.* Ватаным Татарстан

**Тотрыксызланып калу** Нинди дә булса вакыйгадан соң тотрыксызлану. *Былтыр тотылган читән инде кайбер урыннарында басылгандай булган, кайбер урында (иске баганасы черепме, мал-туар ышкылыпмы) кыегая башлаган иде, ә бер төштә бөтенләй тотрыксызланып калган иде.* Н.Фәттах

**Тотрыксызланып китү** Нинди дә булса сәбәптән яки билгеле бер вакыттан соң тотрыксызлану. *[Сәгыйтьнең] бөтен тәне таралып, тотрыксызланып китте ---, теле көрмәлде.* Н.Фәттах

**Тотрыксызланып тору** Даими, һәрвакыт яки әледән-әле, еш тотрыксызлану

**ТОТРЫКСЫЗЛЫК** *и.* Тотрыксыз булу хәле. *Соңгы елларда булган икономик авырлыклар, сәяси тотрыксызлык халыкны үз сәламәтлеге турында уйлаудан читкә этәрде ---.* Ф.Бәйрәмова. *Ул каршылык – кешелек матурлыгы һәм кыяфәт матурлыгы арасындагы каршылык; ышанычлылык, төплелек белән тотрыксызлык, җилбәзәклек арасындагы килешмәүчәнлек.* Р.Батулла

**ТОТСАК** *и. бор.* Тоткын, әсир. *Тотсак өчен йолым түләү*

**ТОТСЫК** *и. бор. к.* **тотсак**

**ТОТТЫРМА** *и. к.* **таккаравыл**

**ТОТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тоту**. *Икенче елны тиз генә кулына бәби тоттырдым да, и шатланды, --- инде уку турында тагын авыз ача алмыйча калды.* Р.Кәрами. *Әтисе, кузгалып китәр алдыннан, кирәк-ярагыңа тотарсың, дип, әбисенә бер уч акча да тоттырды.* Д.Булатова

2) Икенче берәүгә куып җитәргә, үзеңне тотарга мөмкинлек бирү. *Син берәү артыннан дөньяңны онытып куасың, ул тоттырмаска тырыша.* М.Мәһдиев. «*Ярар, кәнфитеңне алам, әмма син мине барыбер тота алмассың», – дип уйлады, һәм киләсе уенда кыз тоттырмады да.* М.Хәбибуллин

3) *сөйл.* Кемгә дә булса бирү, тапшыру; сату. *Сәүдәгәрләр, мактый-мактый, аларга начаррак товар тоттырып җибәрергә тырышалар.* М.Галәү. *--- балдызы, Бүләкне Гайфулланың кулына тоттырып: – Мә, рәхәтләнеп сөй инде кызыңны! Күзеңне майландырып карап торуларыңны күрмәде дип беләсеңме әллә? – диде.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Кемне дә булса дошманы карамагына тапшыру, кулга алдыру, тоткын иттерү. *[Башлыклары] һаман иректә йөри, ди, Исмәт аларны белә, --- патшадан тоттыра икән.* Г.Әпсәләмов. *Ул, үзе җитәкләп алып барып, улын Котырык Муллагалинең кулына тоттырырга һич тә җыенмый иде...* Н.Яһүдин

5) *күч.* Серне ачу, фаш итү. *Сез монда бунт чыгарасызмы? Үзегезне үзегез тоттырасыз ич! Акылыгыз кайда?* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Кемнең дә булса сүзен ялганга чыгару. *Ялганын тоттыру*

**Тоттырып карау** Нәтиҗәсен белү өчен тоттыру. *Ул барысына да курайны тоттырып караган, тик бер генәсе дә курай уйный белмәгән шул.* Р.Батулла. *Тынычрак болын юлларында руль тоттырып караткары да булды.* Г.Сабитов

**Тоттырып кую** Нәрсәне дә булса алдан тоттыру; тиз арада тоттыру. *Акылыннан язган ич инде ул: үлмәс борын кабер урыны сайлап, рәшәткәләр тоттырып куйды бит.* И.Гази. *Авылда да шул яшь чакта кулыма гел гармун тоттырып куялар иде.* Н.Акмал

**ТОТУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне кул белән эләктерү, кулга алу; бармаклар белән яки корал һ.б.ш. ярдәмендә кысу, кыстыру; йомарлау; учлау. *Кызыл чүпрәк белән ураган урагын иңбашына салып, бер кулына савыт белән су, икенчесенә икмәк төргән төенчек тотты ---.* М.Галәү. *– Я, син нәрсә шамакай шикелле гурлаңны киереп торасың, авызыңа төкерим! – дип, Нургалинең юеш бугазыннан учлап тотты да төз лапаска таба этеп җибәрде.* М.Мәһдиев

2) Берәр нәрсәгә кул тидерү, кагылу. *Ул Әхмәтнең кулын кысмыйча, тегеләй тотып караган төсле генә кул эченә алып күреште.* Ш.Камал. *Дамирның йөзе, иреннәре кукшелләнде, ул, күкрәген тотып, үзенә урын таба алмыйча, әрле-бирле йөри иде.* Ф.Садриев

3) Кемнең дә булса берәр җиреннән эләктереп алып җибәрми тору, китәргә ирек бирмәү, юл куймау. *[Карт], үзен тоткан кешеләрнең кулларыннан ычкынып, --- Галимә апага һөҗүм ит[әргә] --- тора иде.* М.Гафури // Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәрәкәтен акрынайту, кызурак хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирмәү. *«Алга, марш!» командасы алу белән, катнашучылар атларын тота-тота, бер-берсе белән тигезләшеп, әкрен генә йөгертә баралар.* Совет мәктәбе

4) Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәрәкәте вакытында аны эләктерү, кулга төшерү. *Иблис ыргыткан шәрабне тоттылар, Күлгә ташларга алып та киттеләр.* Ш.Бабич. *Ә үзем кош тоткандай шатланып --- залга кердем.* Р.Кәрами. *Чөйгән тупны тоту. Тәгәрәткән шарны тоту*

5) Ераклаша, кача башлаган җанлы-җансыз әйберләрне эзәрлекләп эләктерү, куып җитү. *Качсагыз, куып тотам һәм кыйнап ташлыйм.* Т.Миңнуллин. *Шүрәлегә охшашлы бер бәндә бер эшчене куып тотты да, аның бугазына тешләрен батырып, кан эчәргә кереште.* М.Юныс

6) Кошларны, җәнлекләрне яки балыкларны аулау һ.б. *Балык ауларга дисәң, вакыты түгел хәзер, аны иртә беләнрәк тоталар.* С.Җәлал. *– Минем ике овчарка бар, бүре тоталар, – дип мактана башлады лесничий.* Р.Кәрами. *«Күрмисеңмени, кызылканатлар тотам», – дип җавап биргән балыкчы малай.* Г.Гыйльманов

7) Дилбегә, руль һ.б.ш.лар ярдәмендә ат, автомашина кебек нәрсәләр белән идарә итү. *Мин ул тарафка әйләнеп карап, ямь-яшел чапкан печән өстенә ат тотып утырган бер ир, ак эшләпәләр, кызыл күлмәкләр киеп утырган ике хатынны күрергә өлгерә алмадым, анлар бары да бердән атларыннан сикереп төшеп --- йөгереп килә башладылар ---.* Г.Исхакый. *Акулов, әлбәттә, акланып маташкан, ахырда аның ике көн буена улының һәм хатынының туган көнен бәйрәм иткәнлеге, аңа кичә гомумән руль тотарга ярамаганлыгы ачыклана.* А.Тимергалин

8) Хәрәкәт иткән нәрсәне билгеле бер юнәлешкә кую; билгеле бер юнәлештә хәрәкәт иттерүне кулга алу, идарә итү. *Атилла хан йөгерә-атлый баскычлардан төште дә яшьләргә хас җитезлек белән атка атланды, тезгенне тотты.* М.Хәбибуллин. *Ниһаять, картәнисе белән кыз өскә менеп утырдылар, дилбегәне әби тотты.* Д.Булатова

9) Саклау, дәвам итү. *Таң беленгән якка юл тотам ---.* Ф.Кәрим

10) Нәрсәне дә булса төшеп китүдән, авудан, егылудан, җимерелүдән саклап калу; терәк булу. *Авыррак сөякле Мисбах, басма аркылы чыкканда, суга егылып төшә язды. Ярый әле арттан килүче сержант Морозовның көчле куллары аны вакытында тотып калды.* Г.Әпсәләмов. *Баскычта таеп егыла яздым, кемдер тотып калды.* И.Салахов

11) Гәүдәне, әгъзаларны билгеле бер торышка кую. *Разия, фигурасын туры гына тотып, --- вәкарьле генә алдына карап бара.* Ф.Әмирхан. *Җайлап, аркасын терәп, гәүдәсен төз тотып, йомшак креслога утыргач, ул, ниһаять, сәхнәгә күз ташлады.* Р.Кәрами // Берәр нәрсәне билгеле бер торышка, халәткә китерү. *Бабай, кире башы белән тоткансың язуны, печатьле ягын өскә тотып укымыйлар аны, менә болай әйләндереп тот!* М.Гали. *Маһирә ханым профессорга электрокардиограмма тасмасын сузды. Профессор, аны яктыга тотып карый-карый, артистка: – Сөйләгез, сөйләгез, мин тыңлыйм, – диде.* Г.Әпсәләмов // Кемне яки нәрсәне дә булса билгеле бер торышта күпмедер вакытка калдыру. *--- ирләр беркая китмичә, бай йортында ит ашап, кымыз эчеп гомер уздыралар, байтак атларны иярдә тоталар иде.* Г.Ибраһимов. *Башны, кран астына куеп, салкын суда тотам да имтиханга китәм.* И.Салахов. *Карт, --- көч-хәл белән капканы җилгә каршы тотып, атлы кунакны ишегалдының түренә, лапаска таба уздырып җибәрде.* Г.Галиев

12) Кемне дә булса сагалап йөреп кулга, сак астына алу; кулга төшерү. *Ул да булмый, участокка җиткәндә генә әзмәвер Расихтан кулын йолкып алды да, үзе җинаятьчене тоткан кебек эләктереп: – Әйдә, әйдә, тәпиләвеңне бел!* З.Фәйзи. *Кукмара районында кәсеп иткән шушы төр җинаять буенча махсуслашкан караклар шайкасын тотты.* Татарстан яшьләре

13) Күрәсе килгән кешене берәр урында туры китерү, очрату. *Япония пенсионерларын өйдә тотам димә.* Шәһри Казан. *Безнең ветеринария участогы табибы – Фидаил, үзе безнең авылныкы булса да, аны өендә тотам димә.* Татарстан яшьләре

14) Кемне дә булса билгеле бер урында, җирдә булырга, торырга мәҗбүр итү. *Аллаһ әмере белән Юныс пәйгамбәрне Зәлуха исемле балык йотып, үзендә кырык көн әсирлектә тота.* Риваять. *Алар аны ашатты, эчертте, җылы урында тотты, рәнҗетмәде, үз итте, кадерләде.* Р.Мөхәммәдиев

15) Нәрсәне дә булса, саклау өчен, тиешле җиргә урнаштыру. *– Чөгендерне уып, согын салам да бер атна салкынча урында тотам, – дип, имбир маринадлау серләре белән дә бүлеште ул.* Асылъяр. *Масканы биткә сөртеп, 10–15 минут тотам.* Сөембикә. *Банканы сулы кәстрүлгә куеп, су мунчасында тотам.* Шәһри Казан

16) Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәрәкәтенә тоткарлык ясау, аны туктату, кичектерү. *Хәзергә кайтыгыз, уйлагыз, иртәгә керерсез. Мин сезне артык тотмыйм.* И.Гази. *Тик шулай да, Себер*

*дивизияләре килеп җиткәнче, фронтны шул малайлар тотты.* З.Зәйнуллин

17) Кемне яки нәрсәне дә булса мәҗбүри рәвештә билгеле бер халәттә яшәтү. *Күпме илләрне табан астында тоткан, коллыкка дучар иткән, тирә-юньгә бозыклык, азгынлык, канъяшь таратып яткан империя башкаласы юк ителергә тиеш!* М.Галиев. *Габделхәй абзый кияве бүләк иткән коңгырт әтәчне, тавыкларыннан аерып, мунча өйалдындагы чуман астында өч көн рәттән ач тотты.* Р.Батулла

18) Нәрсәне дә булса саклау. *Әхтәри ранный булып ятмыймы, берәр җирдән хәбәре килмәсме дип, соңгы акчаларына сатып алып, шул капчыкларга кипкән өрекләр, урман чикләвекләре тутырып тотты.* А.Гыйләҗев. --- *монда әйберне прилавка астында тоту гадәте юк.* Р.Кәрами

19) Кемне дә булса берәр урында, оешмада һ.б.ш.да эшләтү, яшәтү, калдыру. *Коммунада да андый кешене тотарга ярамый.* Ш.Камал. *Кайтарам! Бер көн дә тотмыйм. Алып кайтам кызны!* Г.Бәширов. *Мин сине өемнән бер минут тотмый куып чыгарыр идем.* А.Шамов // Кемнең дә булса берәр җирдә, урында булуын тәэмин итү. *Сезгә төннәрен җыйналыбрак тору һәм постта кеше тоту кирәк булыр.* Ш.Камал. *Кәримҗан иң мәшһүрә яучыны гына өендә озак тотты.* Р.Батулла

20) Берәр физик халәтне, үзенчәлекне үзендә саклау, чыгармау үзлегенә ия булу. *Тәрәзәнең бер өлгесе ватылды. --- Көндез мендәр тыгалар, кич куна такта каплыйлар. Ләкин бу җылы тотмый.* Г.Ибраһимов. *Сиңа әйтәм, терелеп беткәч, мунча мичен яңартып атарсың әле. Әллә нәмәшләп соңгы арада җылыны тотмый башлады.* А.Әхмәтгалиева. *Буяу тота торган тукыма*

21) Керем, төшем китерә торган берәр нәрсәгә хуҗа булып тору. *Мин фахишәләр турында да язам, ләкин бу – бордель тотам икән дигән сүз түгел.* Ф.Садриев. *Бизнес белән шөгыльләнәм, кибет тотам.* Х.Ширмән

22) Кемне дә булса үз исәбенә асрау, карау, тәрбияләү. *Хаҗи абзый өстеннән унлап сөяркә тоттың.* Т.Гыйззәт. *Җитәр инде, дөм бушка килмешәкләр тотар хәлем юк.* Ш.Камал

23) Берәр нәрсәгә ия булып тору, берәр нәрсәне асрау. *Кәҗәләр алып җибәрдем, тавыклар тотам, дип мактанган була күршем.* Р.Кәрами. *Агачлар болытларга ялгана диярлек, үләне – ат дугасына тиклем: мал кара, умарта тот, киек аула.* Р.Камал

24) Яллау, яллап эшләтү. *Алты баш атка алты хезмәтче тоткан була бу.* Әкият. *Йортта эшче куллар җитешмәү сәбәпле, һәр елны ике-өч кеше яллап тотам, ара-тирә көнлекчеләр дә килеп булышкалый.* М.Галәү

25) Түләү шарты белән башка кешеләрне үз өенә, фатирына кертеп тору. *Биш-алты ай квартирамда буш тотыйм да, җитмәсә тагы үзенә бүлмә дә алып бирим икән!* Т.Гыйззәт. --- *баланы фатирда тоту ата-ана өчен шактый чыгымлы.* Ватаным Татарстан

26) Билгеле максатларда файдалану, сарыф итү. *Артып калган акчаны үз белдегеңчә тотарсың.* М.Галәү. *Юкка гына дүрт тәңкә акча тоттым.* Г.Камал

27) Нәрсәне дә булса запас итеп саклау. *Мин, кенәз, мөселманнарга ярамый торган бернәрсәне дә тотмыйм.* Г.Камал. *Ифтар вакытларында мәчеттә җимеш тотмыйсың.* Т.Гыйззәт // Нәрсәне дә булса кулланмыйча ятку. *Двигателе белән насосларын үткән яз көне алдылар. Эшкә яраклы әйберләрне тоталармыни хәзер!* Ш.Камал. *Заманы, традицион татар өе өчен сирәк күренеш: бүлмәсендә пианино тоткан (бәлки, кызы Өммегөлсем өчен алгандыр).* Р.Әмирхан

28) Файдалану, куллану. *Гәҗитмәҗитләреңне Габдерахман абыең тәмәкегә тотмакчы булган иде.* И.Гази. *Паласымны намазлык итеп тотам.* Казан утлары

29) Берәр урынны әйләндереп алу өчен, берәр нәрсә кору, салу. *Галиулла, язлый бакчасына читән тотып, көз көне кырык төп алмагач утыртты.* И.Гази. *Кемдер сарай сала, кемдер – мунча, кемдер койма тота.* Татарстан яшьләре // Кием-салымның кырыен һәм эскәтер шикелле япмаларның читен нәрсә белән дә булса каймалап чыгу. *– Юк, безгә тәңкәләр кирәкми, менә читенә көмеш ука тоткан куе яшел хәтфә камзул булса икән, – диләр иде аңа.* Ә.Фәйзи. *[Габденнасыйр] ике улына да --- куныч кырыена кызыл сәхтиян тоткан, үкчәсенә яшел сауры салган читек алдырды.* М.Гали

30) Нинди дә булса эш-шөгыль, бурыч, вазифаны башкару, үтәү. *Намазны ул булдыра алган хәтле тиз тотты.* Ф.Әмирхан. *Дивизия белән командалык иткән генерал Волков сүзне кыска тотты.* З.Зәйнуллин. *Шигъри юллар куша-куша, бер ярты сәгать нотык тотты.* Н.Хәсәнов

31) Елганың боз белән каплануы турында. *Елганы боз тоткан*

32) Үзеннән соң килгән фигыльгә кискенлек, катгыйлык өсти; тәвәккәл эш итүне белдерә (барлык формасында гына кулланыла). *«Ярый, – дигән әби, – алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне бөтенләй юк итәм», – дип куркытып куйган ---.* А.Алиш. --- *моннан өч ел элек Гасыйм Сәлахович үзенең ял айларында беркая да китмичә, тотты да шул папкаларын сүтеп актара-карый башлады.* Ә.Еники

33) Тотрыгы, тотнагы булу, егәре җиту. *Тез буыным тотмый башлады.* Ф.Баттал. *Мәрзыя урыныннан тормакчы булып талпынды, ләкин тез буыннары тотмады, кабат урындыгына сыланды.* Д.Гайнетдинова

34) *күч.* Берәр кая бара торган извозчикны, таксины һ.б.ш. транспорт чарасын туктатып утыру. *Әзһәт трамвай тукталышында калды, ә тегеләр өчесе такси тотарга киттеләр.* Р.Кәрами. *Такси тотарга туры килде.* М.Маликова

35) *күч.* Бирелергә, тапшырылырга тиешле нәрсәне бөтенләй тапшырмау яки вакытында бирмәү. *Ничек хәзер кулы барсын Хатны тотып калырга?* М.Җәлил. *Посылканы тапшырмыйча озак тоту*

36) *күч.* Хезмәт хакының, бирeләчәк акчаның яки малның бер өлешен яки тулысынча түләмәү, бирмәү яки кайтармау. *– Миннән дә шул бәя булыр, –*

*диде Малик, – ләкин Галиулланың бирәсеЛәрен шул акчадан тотып калырмын.* И.Гази. *Насыйбуллин! Бәлки, синең хезмәт хакыңны тотып калганнардыр?* М.Хәсәнов

37) *күч.* Теге яки бу эшне эшләүдән тыю, туктатып калу, берәр нәрсә эшләүгә комачаулык итү. *Тик нидер – үлемнән көчле бер нәрсә – аны тотып калды.* Ш.Камал. *Тимер көрәк белән Миңнулланың баш чүмечен куптарып ташлый дигәндә, Маликны чак-чак тотып калдылар.* И.Гази // Берәр төрле хистән тыелу, аны башкаларга сиздермәү. *Минем дә күңелем йомшарды да, ничек тә үземне тота алдым.* Г.Тукай. *Шул куркыныч елларда мин Нәкый абыйдан үз-үземне тота белергә, кирәксез сүзләр сөйләшмәскә өйрәндем.* Р.Батулла

38) *күч.* Һөҗүм объекты итү. *Малаен бу куркыныч җирдән, немец самолётлары бомбага тота торган төштән, нигә алып китәсе килми икән?* Х.Камалов. *Хәрби эшелон өстеннән немец самолётлары оча, берничә мәртәбә утка тоталар.* Р.Мостафин

39) *күч.* Нинди дә булса бер корал белән эш итү, аны куллана белү. *Бервакыт мин Күлле Кимедә балта алып нәрсәдер эшләп маташа идем, Гомәр Бәширов килде дә: «Син балта тотарга кайда өйрәндең?» – ди.* Р.Вәлиев. *Яз-көз айларында исә редакцияләр, өмә җыеп, нәшрият тирәсен җыештырырга чыга: каләм тотарга гына күнеккән куллар тырма, сәнәк, көрәкләр белән коралланa.* Татарстан яшьләре

40) *күч.* Берәр төрле эш белән шөгыльләнү, шөгыльләнә башлау. *[Ул] әнкәсе тоткан бер эшкә үзе керешә.* Ф.Кәрим. *Эшкә йөргәндә өй эшләрен (кер юу, ашарга пешерү, идән юу) кич, төнлә эшли идем, хәзер рәхәт – барын да көндез эшлим, кичен телевизор карыйм, кул эшләре тотам.* Р.Мулланурова

41) *күч.* Баглау. *Ничек инде шушындый егетнең сөйгән яры булмасын, ди, бардыр, өрмәгән урындыкка да утыртмыйлардыр, йорт саен берәр чибәр татар кызы аңа серле мәхәббәтен багышлап, кич очрашуларына өмет тота торгандыр?!* Ф.Яхин

42) *күч.* Нинди дә булса ярамаган эшне фаш итү. *Хан мине кош урлаганда тотты, җиде аргамакны урлап килсәң, кошымны бирәм, дип җибәрде.* Әкият. *Һәрвакыт вак-төяк угры, ялганчыны тоту җиңелрәк инде ул.* Н.Гыйматдинова. *Вакытсыз кайтып, хатыныңны күршең белән тотарсың да, икесен дә атып үтерерсең.* К.Кәримов

43) *күч.* Сизү, сиземләү, тою, аңлау, төшенү; күрү. *Ул Нуруллинның --- нәрсә теләгәнен күз карашыннан тотып ала.* А.Шамов. *Чибәрләнеп торганда, мин үземне: «Галия, боларны бит син Искәндәр өчен эшлисең», – дигән фикердә тоттым.* Г.Кутуй. *Ул, дөм чукрак ук булмаса да, сүзнең күбесен ирен кыймылдауга карабрак тотып алырга тырыша.* М.Мәһдиев

44) *күч.* Радиоалгычны, аппаратны берәр дулкынга корып, берәр радиосигнал яисә радиотапшыру кабул итү, тыңлау. *Радиоалгыч талгын гына гүләргә керешкәч, [Әхияр] тоткасын бора-бора дулкын тота башлады.* Г.Мөхәммәтшин. *Менә бу экраннан дөньяда нәрсәләр булганны күзәтәм, радиоалгычтан Казанны тотам.* И.Хуҗин. *Морат аппаратны токка тоташтырды да кирәкле дулкынны тотты.* Р.Батулла // Радиосигналны кабул итә алу. *Радиоалгычы яхшы тота*

45) *күч.* Идарә итү, идарә итүгә бәйле эшләрне алып бару, башкару. *Тол хатыннар, буыны да ныгымаган сугыш ятимнәре тотты авылны.* Х.Камалов. *Ну, давай, сөйлә: сезнең эшләр ничек анда? Уртавылны кулда тотасызмы әле?* В.Нуруллин. *Ни дисәң дә, тирәюньгә чыксаң, Хафиз бай мактаныч та, авылның терәге дә иде. Мәсҗеден салдырды, мәдрәсәсен тотты.* Ф.Яхин

46) *күч.* Үз тәэсиренә, йогынтысына, хакимлегенә, ихтыярына буйсындыру. *Дию пәрие мине бик каты тотты, беркая да чыгармады.* Әкият. *--- безнең каршыда --- бөтен посёлокны тотып торган атаклы егет Иршат иде.* Р.Кәрами

47) *күч.* Берәр сүз, киңәш, кагыйдә һ.б.ш.ларны тулысынча, әйтелгәнчә үтәү, төгәл эш итү. *Ил сүзен тоткан – ир булыр ---.* Дастан. *Моның белән ул үз ыругсы каршында кадерен тагын беТерде, аксакалларның, өлкәннәрнең киңәшен тотмаганга, аны үз адәмнәре дә шелтәли башладылар.* Г.Ибраһимов. *– Чакыруыңа рәхмәт, Әсәдулла абзый, әмма бара алмыйм, әти картның васыятен тотам, – дип җавап кайтарды ул тегенең тәкъдименә.* Ә.Фәйзи

48) *күч.* Үзен кешеләр алдында билгеле яктан күрсәтү, билгеле рәвештә эш итү, кылану. *Гафият хаҗи үзен бик кунакчыл тотты.* М.Галәү. *Баштарак ул үзен, ничектер, сәер тотты. Буровой эченә керергә курыккандай, күперчек өстенә күтәрелү белән дөньясын онытып катып калды.* М.Хәсәнов

49) *күч.* Берәр кешегә яки әйбергә карата теге яки бу мөгамәләдә булу. *Матур апаны ул җәбер астында тотты.* Ф.Садриев. *Югыйсә ире дә уч төбендә генә кадерләп тота, торырга квартирасы бар, байлык җитәрлек.* Н.Гыйматдинова

50) *күч.* Билгеле бер мөнәсәбәтне, торышны саклау, бозмау, үзгәртмәү. *Төз тот, пионер, сафыңны, нык тор, чамала.* Г.Гобәй. *– Мин дистанцияне тоттым, мсье инспектор! – диде Нуриев.* Р.Батулла. *Җитәкчелек белән ике арада субординация тоту*

51) *күч.* Билгеле бер йоланы, кагыйдәләрне үтәү, башкару; шартына китерү. *Икесе дә амин тотып, бит сыпырдылар.* М.Галәү. *Әмма ничә еллар буе намаз укыган, дин тоткан күрше Равил абый сүзләрен әле өч кенә көн дин дөньясына күчкән малайның кире кагуы дөрес булмас.* Мирас

52) *күч.* Исерткеч эчемлек эчү, эчеп җибәрү, салу, кагү. *Тотып җибәр салганын, тагын бер тот калганын.* Җыр. *Бүтәннәр дә кайсы бер [фужер], кайсы икене тотты.* Н.Хәсәнов. *--- бераздан шау-гөр килеп, берәр стакан тотып, кичкелекне ашадылар ---.* Р.Кәрами

53) *күч.* Вакыт-вакыт кабатлана торган авыру турында: кискен тәэсир итә башлау. *Гаебе зур, белгәч хыянәтен, Бизгәк тоткан кебек чирләдем.* И.Гыйләҗев. *Өянәге тоткан авыру кебек, түшәгендә калтыранып утырган Газинурның иләс-миләс хәлгә төшүен чамалап, Гөлнәзирә үзе дә исен-акылын җуя язды.* Г.Гыйльманов

54) *күч.* Икенче бер кешегә эшләнгән хаксызлык җәза булып кире кайту; каргыш-рәнҗеш төшү; хаксызлык җәзасын күрү. *Ашаткан ашларым, иткән яхшылыкларым тотсын, мәхшәр көннәрендә кулым якагызда булсын!..* Т.Гыйззәт. *Кыскасы, агач каргышы тотты.* Шәһри Казан

55) *күч.* Яшерү, берәүгә дә белгертмәү, сиздермәү. *Сернең дусты күп булыр, серне тоткан бер булыр.* Мәкаль. *Берничә тапкыр йотлыгып суырганнан соң, Челем Хәмидулланың авызы сүз тотмый башлады.* М.Юныс

56) *күч.* Берәр кешегә яки кешеләр төркеменә карата билгеле бер уй-фикердә, мөнәсәбәттә булу, билгеле бер хис саклау. *Кинә тотма, әмма онытма.* Мәкаль. *Тимерчедәге безнең ата филебез, биредәге ана филебезгә бик каты гыйшык тотып, койрыгыннан саргая башлаган икән ---.* Н.Исәнбәт // Саклау, югалтмау, онытмау. *Нурсәлимне сөйгәнен дә, аның әкият илендә калуын да белә иде ул, боларны хәтерендә тотты, әмма бу хакта Гөлйөзем әбигә әйтергә, шуның белән йөрәк серен чишәргә ашыкмады.* Ф.Яхин

57) *күч.* Игътибарга алу. *Укучыларга тәкъдим ителә торган әлеге басма сүзлек составында барган үзгәрешләрне истә тотып, заман таләбенә яраклаштырып төзелде.* Г.Галиуллина. *Әмма дөнья практикасында мәгълүмат базарын, беренче чиратта, милли мәнфәгатьләрне истә тотып җайга салу инде гадәткә кергән.* Фән һәм тел

58) *күч.* Дәрәҗәле урынга ия булып тору, аны саклау. *Авылда гына түгел, математика олимпиадаларында беренчелекне тотам.* Р.Батулла. *Сәнәгатьтә җитештерү күләме буенча республикада беренчелекне Әлмәт тота икән.* Шәһри Казан. *Чаңгы ярышларында беренчелекне тоту. Мактаулы урын тоту*

59) *күч.* Тавыш, ис һ.б.ш. белән билгеле бер урынны, пространствоны тутыру, каплап, биләп алу. *Пароходның берсе кычкыртып җибәрде дә бөтен Идел өстен яңгыратты, икенчесе кычкыртты да калын, куәтле һәм мәһабәт тавышы белән тауларны, урманнарны тотты.* Ф.Әмирхан. *Тотты тавыш бар даланы, тузан алды һаваны.* Гәр.Рәхим

60) *күч.* Нәрсәнең дә булса яхшы, нормаль эшләвен белдерә. *Алай икән, дип уйларга өлгермәдем, машина, таш стенага бәрелгәндәй, кисәк туктады. – Тормозлары шәп тота, – дип куйды баянчы.* Р.Кәрами

61) *күч.* Билгеле бер фикергә килеп, шуны тормышка да ашырып кую. *Шундаен фикерле кызны бер кабахәт кешегә тотып бирсеннәр дә, кызганма, имеш.* Г.Коләхмәтов. *Әгәр дә андый закон чыгарсалар, иң элек безнең Нәгыймәне тотып бирер идек, кешегә әйтергә дә оят: хәзер инде егерме икегә басты.* Г.Камал

62) *күч.* Бәйләнеш, элемтә һ.б.ш тәэмин итү. *--- син менә шушы Яңаул станциясендә яшерен пост булдыр. Һәм ул пост белән даими тыгыз элемтә тот.* В.Нуруллин

◊ **Тотар (тотып карар) җире юк** Бик тә, үтә начар. **Тотарсың (куян) койрыгын** 1) «Инде эш үткән; инде бернәрсә дә эшләп булмый» мәгънәсендә; 2) Берәр җиргә китәргә җыенган кешене теләгән урында калдырып булмаслыкны белдерә. *Әгәр дә норма куйсагыз, тотарсыз койрыгын. Болай да, юкка килдем, китәрмен ахры, дип йөри [ул тимерче].* Т.Гыйззәт; 3) Берәр кешене беркайдан да таба алмауны белдерә. **Тоткан җирдән өзү** *к.* **тоткан җирдән сындыру**. *Безгә хәзер мәми авызлар түгел, тоткан җиреннән өзә торган егетләр кирәк.* Р.Вәлиев. *Әйе, әтием Хәкимҗан бик тә үткен, үҗәт, кырыс, саран, тоткан җиреннән өзеп ала торган, караңгы чырайлы бер бәндә булса да, әнием бик яратты шул үзен.* Ватаным Татарстан. *Язмаларыннан күренгәнчә, Миләүшә алай бик юашлардан түгел бугай, гадәттә андыйлар турында, тоткан җиреннән өзә, дип әйтәләр ---.* Татарстан яшьләре. **Тоткан җирдән сындыру** 1) Үз сүзен сүз итү, үзенчә эшләү. *[Аларның] исләренә төшсә, исләре китә, тоткан җирдән генә сындырырга булсын...* Н.Фәттах; 2) Җитез, эшкә булдыклы булу. *Әйткән сүзен үти торган, кылган гамәлләре өчен җавап тота белгән, тоткан җиреннән сындыра алган ил карты шундый булырга тиеш.* Тамаша; 3) Уйламыйча карар чыгару; дуамалча эш итү. *Булатның Оренбургтагы элемтәләре хакында белгән Зөһрә кулындагы куәтле коралны бик саклык һәм осталык белән эшкә җикте, тоткан җиреннән сындырырга курыкты --- һәм... үз дигәненә иреште дә.* Р.Мирхәйдәров; 4) Кешеләр белән мөгамәләдә артык кырыс булу. *Картинәй атаеңны, бик коры, тоткан җиреннән сындыра торган кеше булган, сине хатыны үлгән бер адәмгә кияүгә бирергә дә талпынып караган, дип сөйли иде.* Казан утлары. **Тоткан җирдән сындырырлык** 1) Бик таза һәм булдыклы кеше турында. *Аша, аша. --- Тазарырга тырыш. --- Тоткан җирдән сындырырлык, баскан җирдән ут чыгарырлык булып үс.* Ә.Фәйзи; 2) Үз сүзен сүз итүчән, җиңүчән, каты куллы кеше турында. **Тоткан җирдән умыру** *к.* **тоткан җирдән сындыру**. *Югары Сөн кызы ич, алар тоткан җиреннән умыра торган...* Р.Мөхәммәдиев. **Тоткан юл** Кемнең дә булса карашы, мәсләге, кыйбласы. *Сезнең авыл халкының тоткан юлы дөрес.* М.Галәү. *– Алар тоткан юл – иң хак, иң дөрес юл, – дип, сүзен бетерде.* Р.Сәгъди. *Тукай өчен төп тоткан юл, әлбәттә, бу чакта да милләткә хезмәт булып чыга ---.* Р.Фәтхрахманов. **Тот капчыгыңны** Көтмә, өметләнмә. *– Беләсеңме, нәрсәдән ясалган ул йолдыз? – дип, мәсьәләне кабыргасы белән китереп куйды берсе. – Рубин, – диде икенчесе, озак баш ватып тормыйча. – Рубин, капчыгыңны киң тот. Рубинның нәрсә икәнлеген белмисең, алайса, син, – дип чәчрәп чыкты өченчесе.* Ф.Хөсни. *– Нәрсә ярты сәгать буе колак төбемдә кигәвендәй безелдисең! Китерер [договорны]! – Тот капчыгыңны! Хәзер эш башланган, безнең туктамасны белә.* Р.Кәрами. **Тот менә** *к.* **тот капчыгыңны**. *Бәлки, ул мине шаһит итеп, гаепләүче итеп чакыртмакчы буладыр. Тотсын менә!* В.Нуруллин. **Тотса мәскәүләр якаң** *иск.* Хуҗалар каршында башыңны иеп яшәргә мәҗбүр булу турында. *Сыймас*

*ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып, Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң!* Г.Тукай. **Тотып алу** Бик тиз төшенү, нәрсәнедер бик тиз аңлау, үзләштерү. *Уразаев политик ситуацияне бик тиз тотып ала белә, моңа аның таланты бар.* Х.Камалов. *Аның сизгер карашы Илсөя күңелендәге үзгәрешләрне тиз тотып алды ---.* Ф.Яруллин. **Тотып ашау** *сөйл.* Бик каты ачулану, тиргәү, гаепләү, җәзага тарту. *Безнең агай-эне бик алама бит ул. Берәр ничек кыек басканыңны сагалап кына тора. Күрдеме, шундук тотып ашарга әзер.* Н.Фәттах. *Каяндыр алтын погонлы чын офицерлар да күренеп ала, боларның кайсысын тотып ашарга микән, дигән сыман бик сынап, караштырып йөриләр.* Әдипләр. **Тотып буу** 1) Кемне дә булса берәр нәрсә эшләргә мәҗбүр итү, ирексезләү; 2) Бик нык ашыктыру. **Тотып та караганы(м) юк** Берәр нәрсәне белмәү, аның белән таныш та булмау. *Чынында исә малайның ул нәрсәне тотып та караганы юк иде.* З.Мурсиев. *Төргәк эчендә – ут янып торган чәчкәле тукыма, аның, шушы яшенә җитеп, мондый матур киемне кию түгел, тотып та караганы юк.* З.Кадыйрова. **Тотып та карамау** Берәр эш-шөгыльгә бөтенләй керешмәү. *Кулларына китап тотып та карамыйча, имтиханнарын да биреп баралар, егетләрнең дә башларын әйләндерергә өлгерәләр.* Идел. *Уку түгел, гәзитне тотып та карамаган ул балаларда ничек татар матбугатына кызыксыну уятасың?!* Мәдәни җомга

**Тота бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы тоту. *Ата белән ана бар эшләгәнен аракы һәм закускага тота барганга, балаларны карарга, киендерергә аның бик аз өлеше генә кала иде.* Р.Сәгъди. *Алтын-көмешне, затлы ташларны, билгеле, элегрәк тә җыйганнар, ләкин булган берен киләккә тота барганнар.* Безнең мирас

**Тота башлау** Тотарга керешү. *Радиоалгыч талгын гына гүләргә керешкәч, [Әхияр] тоткасын бора-бора дулкын тота башлады.* Г.Мөхәммәтшин. *Аннары дошман безне көн саен бомбага тота башлады.* Р.Мостафин

**Тота бирү** Тотуны дәвам итү. *Анда малайлар кармак салып ташбаш та тота башлаганнар. Алар тота бирсеннәр. Безнең эш бүтән.* Н.Хәсәнов

**Тота килү** Күптәннән, электән үк тоту. --- *Закиров элек-электән бер кагыйдәне тота килә: төлке үз оясы тирәсеннән җим эзләми.* Р.Кәрами. *СССР дәүләте үз бюджетының бик күп өлешен Африка, Якын Көнчыгыш илләрендә коммунистик режимны яклаган яшь, яңа системаларга тота килде.* М.Мәһдиев

**Тотып алу** Тиз генә эләктерү, тоту. *Әсфәндияр аның кулын тотып ала.* Т.Миңнуллин. *Изаел күзләрен ачып җибәрә дә кискен итеп Ләмиганың кулыннан тотып ала һәм үзенә таба тартып китерә.* Р.Гаязетдин

**Тотып бетерү** Тулысынча, булганның барысын да тоту. *Ипинең кадагы ике тиен торганда, пирожныйга ун тиен түләп, Мирсәй барлы-юклы акчасын тотып бетерә.* Р.Батулла. *Без артаймыйбыз, һәрвакыт шул халәттә торабыз, чөнки безнең үз резервларын тотып бетергән һәр кузәнәк яңарып тора.* Ш.Алпар

**Тотып калу** Тотарга өлгерү. *Фәридә ашкынып башын күтәрде, бригадирны тотып калырга теләгән сыман, ялварып: – Барый абый, Барый абый!* Н.Фәттах. *– Ярый әле Фаечка тотып калды, юкса үзем дә чума идем, – дип, мичкә ягарга турау өчен Олег аударган коры чыршы өстенә утырды.* А.Хәсәнов

**Тотып карау** Тикшерү, белү, сынау һ.б.ш. максатлар белән тоту. *Музей экспонатларына кагылу, аларны тотып карау тыела!* В.Нуруллин. --- *без беребез дә көтүче Гамис кебек чыбыркы шартлату осталыгына ирешә алмыйбыз, оста итеп шартлата белмәсәк тә, чыбыркысын тотып карау да үзе бер бәхет бит.* М.Галиев

**Тотып кую** Алдан ук тоту; бер тапкыр тоту. *Иртәнге ашыннан канәгатьлек белдереп, ул амин тотып куйды ---.* Н.Фәттах. *Ал стаканыңны кулыңа, тотып куйыйк, китсен үзенең юлына!* Н.Әхмәдиев

**Тотып тору** Әле, хәзер тоту; даими тоту. *Коля багор белән бозны тотып торган арада, Гена боз өстенә сикерде.* З.Зәйнуллин. *«Теш казнасы гына шакылдамаса ярар иде», – дим эчемнән генә һәм иякне ике кулым белән тотып торам.* Р.Кәрами

**Тотып чыгу** Баштан ахыргача, һәр җирен тоту. --- *Сәгъди абзый зиратның ауган ихатасын торгызды, багана утыртып, яңа киртә тотып чыкты ---.* Ә.Фәйзи

**ТОТУЧЫ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең хуҗасы. *Латифа остабикә садакадан килгән сарык йоны белән каз мамыгын Кырлайда кибет тотучы юан Сәхипҗамалдан ун гөрәнкә ярган борчакка алыштырып алып кайтты.* Ә.Фәйзи. *Синең дустың – кабак тотучы Афанасий – синең өстеңнән архиерийга жалоба биргән.* Р.Фәйзуллин

2) Уенда йөгереп качучыларны тотарга тиеш булган уенчы

**ТОТЫК** *и.* 1) Нинди дә булса таләпләрне үтәтү максаты белән кемдер тарафыннан көчләп тотып алынган кеше, заложник. *Узган пәнҗешәмбе санында гына Чаллыда, укол кадауларын даулап, Ашыгыч ярдәм табибларын тотык итеп алган ханым турында язган идек.* Шәһри Казан. *Кытай Шинһуа агентлыгы бер кораллы төркемнең полиция бинасына бәреп кереп, андагы кешеләрне тотык итеп алуын һәм атыш башлавын, кимендә дүрт кешенең үтерелүен белдерде.* Безнең гәҗит

2) *тар.* Дошман якларның яки үзара сугышучы илләрнең берсе тарафыннан нинди дә булса сәяси яки икътисади таләпләрне тормышка ашыру максаты белән кулга алынган яки көчле якка биреп торылган зат; әманәт, рәһен. *Синең углың миндә тотык булып калачак.* Н.Фәттах

**ТОТЫКЛЫК** *и.* Тотык булу, тотык сыйфатында булу. *Күрән би тотыклыкка сиңа башка углын бирер.* Н.Фәттах

**ТОТЫЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тоту**. *Хәтта ындырда өелеп яткан бүрәнәләргә дә файдалы урын табылды: алар булачак яңа мәктәп бинасын салу өчен тотылырга тиеш иде.* М.Галәү. *Әмма ләкин көн яктыра башлагач, далада тотылудан куркып, атларны бер сай чокырдагы ялгыз агачка бәйләп кал-

*дырган.* Ә.Еники. *Кәҗә --- бурлыкта тотылгач, әнидән аңа нык кына эләккәли иде.* М.Галиев

2) Кулланылу, куллануда, файдалануда булу. *Иң элек тартып чыгарганы әз генә тотылган, зәңгәр буяулы тимер чиләк иде.* Г.Ибраһимов

3) Кулланылу, сарыф ителү. *Әгәр спортка тотылган акчаның 25 проценты мәдәният яки башка өлкәләргә сарыф ителсә, без аллы-гөлле Татарстанда яшәр идек.* Р.Батулла. *Явызлык җәзасын таба: Фатихның бала тәрбиясенә тотылмаган байлыгы юкка чыга, Кәрим үлә...* Р.Рахман

4) Бер күк җисеме икенче бер күк җисеме тарафыннан вакытлыча каплану, аның күләгәсенә керү. *Аһ, мин шаһит булдым кичә кояшы тотылганга.* З.Мәхмүди. *Кояш тотылуга ыгы-зыгы, шау-шу, курку башлангач: «Мин – илбашыгыз үтенгәч, Кояш чыгачак», – дип тынычландыра...* М.Хәбибуллин

5) *к.* **тотлыгу** (*1 мәгъ.*). *Мөритнең курыкканлыктан теле тотылып: «Хәзрәт, зинһар, кичерә күр, шайтан кот... кот... котырткан иде», – дигән.* Г.Тукай

6) *күч.* Берәр эш-хәрәкәтне башкарудан тукталып калу, тыелу. *Маркин аның исемен атаудан тотылып калды.* М.Хәсәнов. *Бер үк вакытта Обама «геноцид» сүзен куллանудан тотылып калды.* Мәдәни җомга

◊ **Тотылмаган аюның тиресен бүлешү** Әле эшләнмәгән, эшләнүе икеле булган эшнең нәтиҗәләре турында фараз итү, нигезсез план кору; алдан мактану, шапырыну. *– Эшегез барып чыкса, малны тап урталай бүлешәсезме инде? Яисә башкачамы? – Тотылмаган аюның тиресен бүлмиләр, Миңсылу.* Ш.Камал

**Тотыла башлау** Тотылуга табан бару; тотылырга тотыну. *Урлаганда, бар да батыр, ә тотыла башлагач, һәркайсы шыр җибәрә.* Ә.Еники. *Төш алдыннан Кояш тотыла башлады.* Ф.Зыятдинов. *Утыра торгач, балык та тотыла башлаган.* Сабантуй

**Тотылып бару** Булган берсе эзлекле рәвештә тотылу. *Аларның хезмәт хакыннан ай саен 10–25 процент күләмендә акча дәүләт файдасына тотылып барачак.* Татарстан яшьләре

**Тотылып бетү** Тулысынча, бөтенләй тотылу. *Орлыкка калдырыласы ашлык та шул ук солдатларны ашату өчен тотылып бетте.* М.Галәү. *Ире әйткән букча да тиз бушады, җыйган акчалары тотылып бетте.* Ф.Хәбибуллин

**Тотылып калу** Ниндидер вакыйгадан соң тотылу. *Уҗымнарга көч-куәт бирүче язгы суларның күпме тотылып калуына киләчәк уңыш бәйле булган шикелле, кешеләрнең бу тормышта ничек яшәвеннән гомеренең файдалы өлеше төрле үлчәүдә билгеләнә.* А.Вергазов. *Аның чәчәкле яулыгы, шома чәченнән шуышып төшеп, толымнары төбендә генә тотылып калган.* М.Маликова

**Тотылып килү** Электән үк, эзлекле рәвештә тотылу. *Алдан ук хезмәт хакыннан ел буена шуның суммасы тотылып килә.* Кәеф ничек?

**ТОТЫЛУ** II *и. астр.* Бер күк җисеменең, арага башка бер күк җисеме керү сәбәпле, тулысы белән яки бер өлешенең күренми торган хәлгә килү күренеше. *Ул, Ай һәм Кояш тотылуларын өйрәнү максатыннан, төрле җирләргә сәяхәт кыла ---.* Гасырлар авазы. *Аспирантурада укуның беренче елында ук ул үзгәрүчән йолдызларга кагылышлы һәм 1940 елны Кояш тотылуны күзәтү нәтиҗәләренә багышланган өч фәнни хезмәт бастырып чыгара.* Фән һәм тел

**ТОТЫЛЫШ** *и.* Күк җисемнәренең тотылу күренеше. *Тотылыш вакытында Ай гадәттә бөтенләй күздән югалмый, аз гына булса да күренеп тора.* Астрономия

**ТОТЫЛЫШЛЫ** *с. астр.* Тотыла торган. *Тотылышлы куш йолдызлар*

**ТОТЫМ** *и.* 1) Тотылган балык яки ауланган кошлар күләме. *Кояш биеккә – горизонт өстенә күтәрелде, балыкчылар үзләренең беренче ятьмәләрен чыгаралар. Хуҗаларның кояшта кызган битләрендә шат елмаю: менә ул бәхет – яхшы һава торышы, уңышлы тотым, балыкның суда тибрәлүе, ә балык – милли байлык.* Ватаным Татарстан

2) *к.* **тотам**. *[Кеше] кулына бер тотым үлән йолкып ала.* К.Насыйри. *Бер тотым да болыт бизәкләми Уңа төшкән аяз җәй күген...* Ф.Галиева

**ТОТЫНГЫЧ** *и. сөйл.* Басма, баскыч һәм күперләр кырыйларындагы тотыну өчен ясалган арата, култыкса. *--- аны милиция йортының балконында, курткасының бер җиңен балкон тотынгычына бәйләнгән көе, икенчесен муенына уралган килеш милиция өлкән лейтенанты таба.* Г.Газиз

**ТОТЫНУ** *ф.* **1.** 1) Берәр нәрсәгә кул белән ябышу. *Ул, агачка тотынып, бер урында сикергәләде.* И.Гази. *Аерылмас өчен, йоклаганда да, Җәүдәткә тотынып йоклаган Җомай Габдрәхиме өчен тынгысыз көннәр җитте.* З.Зәйнуллин. *[Карт] таягына ике куллап тотынды да тирә-юньгә күз салып сорады.* Д.Гайнетдинова

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса орыну, кагылу, тию. *Ләкин санитар – сүзсез буйсынырга өйрәнгән кеше булса кирәк – кабельгә тотынып өлгерде.* А.Тимергалин. *Яшел мүк белән капланган черек бүрәнәләренә сак кына тотынып, кое күзенә үрелеп карады.* Г.Гыйльманов

3) Бер-беренең кулларыннан тоту. *Башкалар, тотынып, әкрен генә җырлый-җырлый, аңа киләләр.* М.Җәлил. *Тик бу юлы алар бармакларын аралаштырып, кулга-кул тотынып утырдылар.* З.Мурсиев

4) Нәрсәне дә булса кулга алып, әзерлек хәлендә тору. *Сугышчылар, коралларына тотынып, тын да алмыйча көтә башладылар.* Г.Әпсәләмов. *Җөри хан, әллә ничә тапкырлар коралга тотынып, мангулларга каршы үзеннән-үзе кабынып киткән күтәрелешләрдә катнашып караса да, --- вакыты җитми торып кылычны кыныннан чыгармаска, дигән карарга килде.* М.Хәбибуллин

5) Нинди дә булса эшне башкарырга, үтәргә керешү, башлау. *[Нуретдин:] Чынлап тотынганда, иң якын елларда фермабызның игелеген күрә башларбыз.* Ә.Еники. *– Әйдә, Зөбәер, бу эшкә син тотын әле, – диделәр.* Д.Булатова

6) Нинди дә булса эш белән шөгыльләнә башлау. *Атны тугарып, арбасына печән ташлап, тезгенен арба аратасына бәйләп, Кәримҗан мәзин җиң сызганып --- уракка тотынды.* Р.Батулла. *Хафиз байдан соң бөлгенлеккә кадәр*

*китереп җиткерелгән кибетенә тәртип салды, эш кәгазьләренә тотынып, әле җан бирергә өлгермәгән сәүдәләрен яңартып җибәрде.* Ф.Яхин

7) *диал.* Нәрсәдән дә булса тыелу; туктау. *Сәгыйдә тотына алмый үкси.* Һ.Такташ. *Дилүгә дә үзенә тиңнәр табып, яңа тормышка күнегәсе калды. Тик хәмергә генә тотынмады.* З.Кадыйрова

**2.** *ярд. ф. мәгъ.* Керешү, башлау. *Әти, кычкырып, «Әлхәм» укырга тотынды.* Г.Исхакый. *Миңлебай дуларга, «чыгам, ватам» дип җенләнергә тотынды.* Г.Ибраһимов

◊ **Тотын гына!** *сөйл.* Берәр эшхәрәкәтнең бик көчле, интенсив башкарылуы яки башкарылачагы турында; чыда гына, түз генә; чыдап кына, түзеп кенә тор. *[Яңгыр] бер ява башлагач явар инде. --- Бер елны да башта шулай булган иде. Шуннан сала башлады – тотын гына!* Ш.Камал

**Тотына башлау** Эш тотынуга барып җитү; тотынырга керешү. *Иллә сугыш чыгып, читән казыгына тотына башласалар, я кирегә, яисә алга таба торып йөгерергә туры килә.* З.Зәйнуллин

**Тотынып калу** Үз вакытында тотынырга өлгерү. *Урыннарында ничектер тотынып кала алганнары, актык көчләрен җыеп, абына-сөртенә, таяегыла, бәлагә эләккәннәренә ярдәмгә ташландылар.* М.Галәү. *Ян тараftан китереп сылаган кар өермәсе һәм ачы җил чак аяктан бәреп екмады, чана үрәчәсенә генә тотынып калдым.* Р.Мөхәммәдиев

**Тотынып карау** Тотынырга тырышу; булу-булмавын сынау өчен тотыну. *Нинди генә эшләргә тотынып карамый ул!* М.Галәү. *Әйтик, инженер-конструктор бер техник мәсьәләгә теге яктан да, бу яктан да тотынып карый, ничәмә-ничә җайланманы, механизмнарны күздән кичерә, ләкин уена яраклы конструкция килми.* А.Тимергалин

**Тотынып тору** Тотынган хәлдә булу; даими, һәрвакыт тотыну. *Коеның диварына бер микъдар тотынып торырлык җир ясамакчы була, әмма мөмкин түгел.* К.Насыйри. *Ул бераз вакыт тимер рәшәткәгә тотынып торды.* Р.Вәлиев

**ТОТЫНЫШ** *и. к.* **тотыш** I. *Аңарда ирләр тотынышы һәм ирләр көче бар.* Ш.Камал

**ТОТЫНЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тотыну**. *Икенче көнне Нәзифә белән Нәсим, кулга-кул тотынышып, тау астындагы чишмә буена төштеләр.* Ф.Зариф. *Яшьләр тотынышып биилләр, җырлыйлар.* Н.Хәлимова

2) *диал.* Көрәшкәндә бер-беренә ябышу; бер-береңне эләктерү. *Алар билдән тотынышып алыша башладылар.* А.Әхмәт

**Тотынышып тору** Тотынышкан хәлдә булу. *Шобага яки санашу юлы белән берәүне көтүче итәләр дә, калган балалар, бер түгәрәк ясап, берберсенең кулларына тотынышып торалар.* Р.Ягъфәров

**ТОТЫШ** I *и.* Җәмгыятьтә, кешеләр арасында кылына торган гамәлләр әдәбе; кемнең дә булса үз-үзен тоту рәвеше. *Малайларга аларның сүзләреннән бигрәк үз-үзләрен тотышы кызык тоелды.* Р.Мөхәммәдиев. *Юк, дияр иде, үзен тотышы, битенә йөгергән кан аның белгәнлеген кычкырып тора.* Ф.Латыйфи

**ТОТЫШ** II *с.* **1.** *диал. к.* **тоташ 1.** *Бик иске заманда Шырдан белән Бәчек авылы арасы тотыш бик зур урман булган.* К.Насыйри

**2.** *рәв. мәгъ.* Туктаусыз, өзлексез, тоташтан. *Балыкчының тамагы ач булыр имеш, тотыш йөрсә дә балыкка.* Г.Кандалый. *Яңгыр инде бер-ике көннән бирле тотыш ява иде.* Ш.Камал

**ТОТЫШЛЫ** *и.* Бер-береңне куып тотуга нигезләнгән уен. *Урамда балалар тотышлы уйный*

**ТОТЫШТАН** *рәв. диал. к.* **тоташтан**. *Шәрәф ишан, Гыймад таз, Сөнгать куштан Типтерәләр тотыштан, эшләмичә.* М.Крымов

**ТОТЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тоту**. *Сафа белән Саҗидә кулга-кул тотышып урам буйлап киттеләр.* М.Галәү. *Минҗан карт, трубкасын кабып, ат абзарына килә, малайларга атларын тотыша ---.* М.Мәһдиев. *Кайсы әбинең бакча коймаларын тотыша, кирәк чакта карын көри, идән-сәкесен юып чыгара.* Сабантуй

2) Шобага салуның бер ысулы буларак, берәр озын әйберне (таяк, сөлге һ.б.ны) чиратлашып берәм-берәм тотып чыгу (кулы иң өстә калган кеше җиңүче була); тотам тоту. *Шунда Рәниф сынык чалгы сабы табып алды да, әйдә, шобага салабыз, Сафуан, ди. --- Бәхәсләшә-хәрәмләшә ике мәртәбә тотышканнан соң, Рәниф өскә чыкты.* М.Галиев. *Сайлау процедурасы, берниндн фальсификациясез, озын таяк җитмәсә, дилбегә тотышып үткәрелә.* Ф.Сафиуллин

3) Билдән тотып көрәшү, бер-берен егарга тырышу; алышу. *Менә ул берьер артлы башка ырулардан килгән батырларны бәреп төшерә. Бил тотышып көрәшкән алыпларны аркаларына сала.* Р.Сәгъди

**Тотыша башлау** Тотышырга керешү. *Алар тотыша башладылар, бармакларын берсе өстенә берсен куйдылар.* Х.Камалов

**Тотышып карау** Сынау максаты белән тотышу. *Көрәшергә исәп булганга, без --- түгәрәк эченә аяк бөкләп утырдык. Бераз торгач, староста, утырган урыныннан торып: «Ягез, балалар, тотышып карагыз әле», – диде.* М.Гали

**Тотышып тору** Тотышкан хәлдә булу. *Минем башка егет белән кулга-кул тотышып торуымны күрде.* Р.Галиуллин

**ТОФӘЕЛ** *и. гар. иск. к.* **тофәйли**

**ТОФӘЙЛИ** *и. гар. иск.* 1) Чакырылган кунакка ияреп, чакырылмаса да, кунакка баручы кеше; чакырылган кунакка ияреп килүче

2) Кеше нишләсә, шуны эшләп йөрүче кеше; үз фикере булмаган, фикерсез кеше. *Шәһәр тофәйлиләре*

3) Гадәттә тар карашлы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы кеше; обыватель. *Мәхәлләдәге барлык сез әйткән тофәйли динен дә, телен дә оныт[кан].* А.Расих

**ТОЧ** *и. фар. иск.* **1.** Бронза. *Точтан коелган сын. Точ кисәге*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бронзадан ясалган, бронзадан коелган. *Точ пычак. Точ савыт*

2) *диал.* Саллы, тыгыз. *Точ агач суда да батмый*

**ТОЧЛЫК** *и. диал.* Тыгыз, саллы булу; чагыштырма авырлыгы зур булу

**ТОШ** I *и. диал.* Тирә, ара (вакыт тур.). *Шушы бер-ике ай тошында булган хәл*

**ТОШ** II *и. диал.* 1) Төш (чикләвек, чия, өрек һ.б.ш.ныкы). *Каражимеш тошы*

2) *кулин.* Төш, бавырсак. *Тош пешерү*

**ТОШЛЫ** *с. диал.* Тошы II (*1 мәгъ.*) булган. *Тошлы йөзем*

**ТОШЛЫК** *и. диал.* Камыр ашларының эченә салына торган эчлек

**ТОШМАЛА́У** *ф. диал.* 1) Билгеләнгән вакыттан икенче, соңрак вакытка кичерү, чигерү, кичектерү. *Бурыч түләүне тошмалау. Мәсьәләне хәл итүне тошмалау*

2) Чамалау, чалымлау. *Күптәнге танышын тошмалады*

**ТОШЫГУ** *ф. диал.* Юлыгу, очрау, тап булу. *Саранга тошыкма, тошыксаң – пошыкма.* Мәкаль. *Авыр эшкә пошыкма, тошыксаң – пошыкма.* Мәкаль

**ТОЮ** *ф.* 1) Сизү органнары ярдәмендә объектив чынбарлыкны кабул итү, аның аерым билгеләрен сизү. *Бара-бара да арба төбенә салынган көл капчыгын капшап карый, аның әле суынып бетәргә өлгермәгән җылысын тоя.* Н.Хәсәнов. *Ак бабай күрсәткән урынга уч төбемне куйдым һәм тамырдан узып торучы җиңелчә тибешләрне тойдым.* Р.Нуруллин

2) Берәр нәрсәне белү, күңел белән сизү, сизенү. *Синең тормышыңда мин белмәгән нәрсәләр бар, күңелем шулай тоя.* Ф.Садриев. *Күңеле белән иң якын кешеләренә өч сүз җиткәнен дә тоя, тик менә өч сүзне язу өчен, Мансурга өч сәгать утырырга кирәк.* Х.Ширмән

3) Аңлау, төшенү. *Мин тормышның ашау-эчү, кар көрәү, маймыч сөзү, таң ату һәм кич булу кебек хәлләрдән генә тормавын, дөньяда боларның барысыннан да өстенрәк һәм аңлаешсыз нindидер нәрсә булуын тойдым.* Р.Вәлиев. *Бу дөньяга кирәк түгеллегем тойдым.* Г.Мөхәммәтшин

4) Үзен берәр ничек хис итү. *Бәһрам бәк алдында ул үзен гаепле тойды.* М.Хәбибуллин. *Кызыксыну шундый зур булгач, өстәвенә делегациянең рәсми җитәкчесе дә саналгач, мин һәр чыгышым өчен үземне җаваплы тойдым.* Р.Фәйзуллин. *Үземне музейга куелган тере экспонат итеп тойдым.* Ф.Зариф

5) Билгеле хис, тойгы кичерү, тату. *Халык, үзенең тагын әллә нинди үчләрен алган төсле булып, үзендә сәер бер кинәнү тоя иде.* М.Галәү. *Чыннан да, Зариф, беренче мәртәбә сугышка керүенә карамастан, үзендә аңлавы читен булган бер тынычлык тоя иде.* Ә.Еники

6) Үз организмыңның билгеле бер халәтен сиземләү, сизү. *Ашыйсы килүен тою. Йокы килүен тою*

7) *күч.* Теге яки бу сыйфатны, үзенчәлекне һ.б.ш.ны табу, күрү. *[Зариф та] шушы минутта үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр.* Ә.Еники. *Ул шунда икесенең дә үзара охшашлыкларын тойды*. Ф.Яхин

**Тоеп алу** Тиз арада, кинәт тою. *Бәһрам шаһзадә ни кылганын арысланнарга якынайгач кына тоеп алды ---.* М.Хәбибуллин. *Әхмәтсафаның кулына үги әнкәнең шәрә боты тиеп китте, битен ялмап алган итәк җилен тоеп алды.* Ф.Сафин

**Тоеп җиткерү** Тәмам, ахыргача тою. *Тик бәла якадан килеп алмый торып, адәм баласы аның бөтен ачысын тоеп җиткерми бит әле.* Д.Гайнетдинова

**Тоеп йөрү** Һәрвакыт тою. *Очынып өй бизәп йөргәндә дә, сулы чиләкләрне җиңел уйнатып бианасына булышканда да, ул Гаянның сокланулы карашын тоеп йөрде.* Ә.Дусайлы. *Менә бер ай инде күзәтеп йөрим, күзәтеп кенә түгел, тоеп йөрим: нишләптер, син миңа туганым кебек якын, шулкадәр якын – бер нигездә яшәгән кардәш җаннар кебек без синең белән...* Сөембикә

**Тоеп килү** Күптәннән тою. *Мин аларның үземә карата хәерхаһлыгын тоеп килдем.* Ватаным Татарстан. *Күреп, үз җилкәбездә тоеп киләбез: халыкка яхшы киләчәк вәгъдә итеп башланган реформаларның барысы да, нигездә, гел аның өстенә авыр йөк булып төшә.* Мәдәни җомга

**Тоеп тору** Хәзер, шушы вакытта яки һәрвакыт тою. *Ирем дә бәхетле – мин моны сизеп, тоеп торам.* Г.Гыйльманов. *Шуннан бирле гомер буе ниндидер югары көчләр мине үлемнән һәм авырлыклардан саклап килүен тоеп торам.* Р.Нуруллин

**Тоя бару** Торган саен ныграк тою. *Җил улаган саен, Нурисламжылы урынның ләззәтен ныграк тоя бара.* Р.Батулла

**Тоя башлау** Нәрсәнедер тою барлыкка килү. *«Барысы да миңа үч итәләр...» – дип уйлап, үз-үземне бик җәберләнгән кеше шикелле итеп тоя башладым.* Ф.Әмирхан. *Нянялар калаклап ашаткан боткаларның да тәмен тоя башлады.* Д.Булатова

**ТОЯК** *и.* 1) Ат, сыер, сарык һ.б. кайбер имезүче хайваннарда аяк очын – җиргә баскан төшне каплап торган мөгез катлау. *Әйе, [болан баласының] бөтен җире саргылт, тик авызы белән тояклары гына кара иде...* С.Җәлал. *Урамда арба шыгырдавы, тояк дөпелдәве һәм Нәфисәттәйнең: «На, үшән!» – дип, ат куган тавышы ишетелде.* Ф.Шәфигуллин

2) *күч.* Йодрык, кукиш. *Тояк күрсәтү*

◊ **Тоягы җиргә тимәү** Бик тиз йөгерү. *Айратның аты сөлек шикелле. Тими дә кебек Тоягы җиргә, Зур калын ялы чайкала җилдә.* З.Мансур. *Ядрунның тояклары җиргә тимәде, авылга тикле ук кебек очты.* В.Ильясов. **Тоягын күтәрү** Үлү. **Тояклар күтәрелү** Егылу. *– [Үгез] бер китереп мөгезләре белән бирсә, тоякларыгыз шунда ук һавага күтәрелер. – Ега алмас, безнең аяклар җиргә нык ябышка初 каннар.* К.Нәҗми. **Тояк суы эчкән** Дөньяда күпне күргән, төрле авыр, читен хәлләрне башыннан үткәргән, кичергән, тәҗрибәле. **Тояк ялтырату** Качу; табан ялтырату. *Әгәр бүген безнең батарея тау башына урнашмаган булса, без бик күптән тояк ялтыраткан булыр идек...* А.Шамов

**ТОЯКЛЫ** *с.* Тояклары булган. *Ә юлдагылары, озын яллы, стакан тояклы аргамакларын тимердән үргән камчылар белән кыздырып, һаман алга таба чабалар да чабалар, ди...* А.Алиш. *Ут тояклы атлар, үткен күзле мәргәннәр, батыр йөрәкле сугышчылар синең үзеңдә.* М.Хәбибуллин

**ТОЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Тояклы планцентар имезүчеләр өсотряды;

*русчасы*: **копытные**. *Галәм агачының төрле өлешләре аерым аллалар яки кош-хайваннар белән бәйләнгән булырга мөмкин: агачның ботаклары – кошлар, әйтик, бөркет; урта бер җире – тояклылар: болан, сыер, ат; тамырлары – елан, бака ---.* Ф.Урманче. *Ярымчүлләр һәм чүлләрдә күбесенчә кимерүчеләр һәм тояклылар яши.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТОЯ́К-ТӨЙКӘ** *җый. и.* 1) Һәртөрле тояк, тояклар

2) *күч.* Вак-төяк, әһәмиятсез, арзанлы нәрсәләр. *Безгә тояк-төйкәләре генә калу*

**ТОЯ́К ҮЛӘНЕ** *и. биол.* Кирказончалар семьялыгыннан урманда үсә, үзеннән борыч исе яки тәме килә һәм халык медицинасында бизгәктән, эч катудан, костыру өчен кулланыла торган, кыска сабаклы, тояксыман эре һәм каты яфраклы күпьеллык агулы үлән; тайтояк; *русчасы:* **копытень**. *Тояк үләнен --- костыручы дарулар җөмләсеннән истигъмаль кылалар.* К.Насыйри

**ТОЯНА** *рәв. диал.* 1) Тавышсызтынсыз, тыныч. *Тояна йөрү. Тояна яшәү*

2) Бирелеп, онытылып, мавыгып. *Тояна уйнау*

3) Көтмәгәндә, кинәттән, искәрмәстән. *Тояна килеп чыгу*

**ТӨБӘК** *и.* 1) Җир йөзендә билгеле бер урын, як. *Гази бит үзенең бөтен киләчәген, өметен шушы төбәк белән бәйләрмен дип уйлаган иде.* М.Хәсәнов. *Төбәк һәм милләтләрне өйрәнүчеләр өчен бу кичектерү хәтта фаҗигале, дип әйтеп була.* А.Кормаш

2) Эре административ берәмлекнең кечерәк өлеше; район; регион. *Урманкүлләргә, чәчкәле болыннарга бик бай төбәк бу.* А.Хәсәнов. *Татар дөньясында үзенең ямьле Ыклары, моңлы Зифалары, шигъри Зөлфәтләре, күпләгән талантлары белән мәшһүр булган Мөслим төбәге дә бар.* Х.Миңнегулов

3) *сөйл.* Торак пунктның бер очы, мәхәлләсе, урамы. *Эше беткәч, уйга кала, аягы тартмый, кире аулак таныш төбәгенә борыла.* Г.Хөсәенов. *Рифалар шушы бригада төбәгендә торганга күрә, Мирхаслар белән бер табынга ашка чакырылды.* Х.Камалов

**ТӨБӘКЛӘП** *рәв.* 1) Аерым төбәкләр буенча. *Милли аң сүнүен төбәкләп бизмәнләү мөмкинме?* Т.Әйди. *Шуңа күрә аны төбәкләп (Себер, Ерак Көнчыгыш, Төньяк, Урал, Идел буе...) өйрәнү фәндә һәм гамәлдә кулланыла.* Х.Миңнегулов

2) Берәмләп, мәсьәләнең һәр ноктасын аерым-аерым карап. *Ул үзенең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле китабында (1925) төбәкләп өйрәнү принцибын эзлекле төстә гамәлгә ашырды.* А.Фәтхи

**ТӨБӘКЧЕ** *и.* Төбәкнең тарихын, географик, этнографик һ.б.ш. үзенчәлекләрен өйрәнүче

**ТӨБӘКЧЕЛЕК** *и.* 1) Гомуми, уртак эшкә зарар китерү хисабына, урындагы тар мәнфәгатьләрне генә кайгырту; урынчылык. *Төбәкчелек фикерләре*

2) Билгеле төбәк, урын белән бәйлелек. *1920 нче елларга кадәр кайбер төбәкчелек исемнәренең (мишәр, типтәр, керәшен, бохарлы, нугайбәк, карагыш) саклануы татарларда этник консолидациянең тәгәлләнеп җитмәгәнлеге белән аңлатыла.* Д.Исхаков

3) Төбәкне өйрәнү фәне. *Дөресен әйткәндә, минем төбәкчелек белән шөгыльләнә башлавыма... татар тарихчы-галимнәренең бу өлкәдәге эшсезлекләренә үртәлү сәбәп булды.* Ж.Рәхимов

**ТӨБӘЛҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төбәү**. *Чөнки аның әлеге күпне күргән агач аягы сиңа төбәлгән кул пулемётын хәтерләтә.* А.Хәсәнов. *Башына төбәлгән йодрык күкрәгенә генә эләкте.* Р.Сәгъди

2) Текәлү (күз, караш тур.). *Аннары авызын ачып, Әшрәфҗановның йөзенә төбәлде.* Ф.Садриев. *Нәкъ Сөләйманныкы кебек чем кара күзләр яратып, үз итеп аңа төбәлгән, җанны эретерлек бу назлы караш, сихри нурларга, җылы томаннарга төреп, аны ниндидер серле, яңа дөньяга чакыра иде.* Р.Габделхакова

3) *күч.* Кемгәдер билгеләнү, билгеле кеше яки кешеләр төркеме өчен генә әйтелү, эшләнү, язылу, юнәлү, эшчәнлек алып бару. *Туфан үзе – бөтен барлыгы белән халыкка төбәлгән кеше.* С.Хәким. *Бу иҗат мине күрегез дип кычкырып тормый – ул үзенә хас җентекләүне, текстка һәм сүз артындагы мәгънәләргә игътибар итүне сорый: чыннан да, бу иҗат яшәешне, тормыш агышын аңлап, гыйбрәтләр һәм сабаклар ала белүчеләргә төбәлгән.* Р.Сверигин

4) *күч.* Планлаштырылу, исәп тотылу, күздә тотылу. *Аларда инде яңа төсмерләр, киләчәккә төбәлгән яңа мотивлар.* Р.Фәйзуллин. *Әллә авторның интеллектуальлеге киләчәккә төбәлгәнме, фәнни-фантастик әсәрме бу?* Идел

5) *күч.* Аерым кешегә яки нәрсәгә төшү, туры килү, эләгү, билгеләнү. *Бу дөньяның чәнечкеле уклары нигә миңа гына төбәлгән?* Н.Хәсәнов

**Төбәлә төшү** Бераз төбәлү. *Картыбыз, бар күк җегәрен җигеп, төбәлә төшебрәк бермәл миңа карап торды да, мелт-мелт кыймылдап торган иреннәре арасыннан һич көтелмәгән сискәндергеч көчле тавыш белән: – Бакчы... Пәтыйх түгелме соң?.. Пәтыйх үзе ич бу! – дип кычкырып җибәрде.* Ф.Хөсни

**Төбәлеп калу** Төбәлгән хәлгә килү. *Дугаланып бөгелгән озынча керфекләре салмак кына тибрәлеп алды, һәм серле карашлары миңа төбәлеп калды.* Н.Хәсәнов

**Төбәлеп тору** Озак вакыт төбәлгән хәлдә булу; сөйләү моментында төбәлү, гел төбәлү. *Ул озак кына иртәләгән көзгә төбәлеп торды.* Ф.Җамалетдинова. *Бертын алар бер-берсенә төбәлеп тордылар.* С.Гаффарова

**ТӨБӘЛҮ** II *ф. диал.* Яшәү өчен бөтенләйгә урнашу, төпләнү. *Ирексез авылга кайтып, бөтенләй шунда төбәлергә туры килде.* М.Гали

**ТӨБӘҮ** *ф.* 1) Ату коралын һ.б.ш.ны кемгә-нәрсәгә юнәлдерү, юнәлтү, төзәү. *– Дәшмә, Күчем! – дип, Ураковның урыныннан сикереп кузгалуын әмер төсле кабул итте ахры, аның янындагы бер офицер Күчем батыр күкрәгенә мылтык төбәде.* В.Имамов. *Дилүс үзенә уктала башлаган Булатка автоматын төбәде: – Стоп!* Г.Гыйльманов

2) Нәрсәне дә булса икенче бер нәрсәгә таба бору, карату, юнәлдерү. *Пультны телевизорга таба төбәү*

3) *күч.* Берәр нәрсәгә яки кешегә юнәлтү, текәү (күз, караш тур.). *Мөлдерәмә яшь белән тулганга тоныклана төшкән зур күзләрен яңадан Мансурга төбәде.* Г.Әпсәләмов. *Кара хатын усал карашын Алинәгә төбәде.* Х.Ширмән

4) *күч.* Кемгә-нәрсәгә табан, шуның юнәлешендә турылап. *Моңа кадәр Фәнис белән Нәзирә артында посып утырган Айгөл куенындагы плүш аюны аларга төбәп килә башлаган ерткыч җанварга ыргытты...* Г.Гыйльманов

5) *күч.* Кемгә-нәрсәгә билгеләү, махсус атау, адреслау, мөрәҗәгать итү, юнәлдерү. *Җаббаровка төбәп әйтелгән соңгы сүзләрдән соң, Айрат Бәдретдинович урыныннан торып алгарак үтте, Җаббаров моңа каршы ни әйтер икән дип, аңа текәлде.* А.Вергазов. *Егет, Хариска төбәп: – Кара эчле абзый син, – диде.* Н.Гыйматдинова

**Төбәп алу** Азга гына төбәү. – *Каяле, мин кухня белән ике арада йөргәндә, сезнең дә күңелне күтәрә торсын, – диде дә кыз кәнәфидә яткан пультны түр башындагы телевизорга төбәп алды.* Ф.Баттал

**Төбәп кую** Төбәлгән хәлгә китерү; алдан ук төбәү. *Алгы аяклары белән җир тырнап, муен өстендәге йонnaрын кабартып, очлы мөгезләрен аңарга төбәп куйган бу иләмсез һәм шыксыз тәкәнең кан сауган күзләреннән генә дә куркып качырлык...* Р.Мөхәммәдиев. *Нәҗип «бисмилла» әйтте дә күпердән бер яккарак төбәп куелган туптан атып җибәрде һәм көлеп куйды: тупны борып куймаган булса, күпер бу юлы ук юкка чыккан була иде.* И.Хуҗин

**Төбәп тору** Озак вакыт төбәгән булу; гел төбәү; хәзерге моментта төбәү. *Һаман аларга сораулы карашын төбәп торды.* Х.Камалов. *Аннары, күзләрен урам якка төбәп торган килеш, тыныч кына әйтеп куйды: – Килеп җиттек...* Г.Гыйльманов

**ТӨБЕНӘ́ЧӘ** *рәв.* 1) Тулысынча, беткәнче, төбенә кадәр (эчү, ашау һ.б.ш. тур.). *Йокы булмәсенә кергәч тә, ул әлеге алтын кувшиндагы шәрабны төбенәчә эчеп бетерә.* Ф.Урманче. *Әйе, алдыңдагы ул касәне төбенәчә чөмереп бетермәгәнсең.* Р.Камал

2) Бөтен киңлегенә. *Әйтерсең аларның берсе менә хәзер ишекне төбенәчә каерып ачыр да, тир белән кушылып кара мазут аккан йөзләренә ачы нәфрәт чыгарып, текәлеп карар кебек иде.* А.Вергазов

**ТӨБЕНДӘ** *рәв.* Нигездә; асылда, чынлыкта, чынында. *Халикъ абзый төбендә Шихрай турында дөрес [искәрмә] ясады.* Ш.Камал. *Төбендә ул үзе бер булса да, исәбе һәм эше ягыннан, ак, көрән һәм кара сыйфатларын «ал»лаштырып йөргән «халык» бар.* Х.Туфан

**ТӨБЕННӘН** *рәв.* Бөтенләй, тулысынча, тәмам; нигезеннән. *Тормышымны төбеннән үзгәрткән марҗа кызы Лиданы озак эзләсәм дә, башка күрә алмадым мин.* М.Әхмәтшина. *Ул фикерләрнең төбеннән үк ялгыш икәнлеге ачыкланды.* Мәйдан

**ТӨБЕТ** *и. кыт.* Ерткыч хайваннар аулау, көтү көтү өчен файдаланыла торган авыр сөякле эре эт токымы; *русчасы*: **мастиф**. *Исеме телгә алынмаган егеттән исеме телгә алынган төбет артык.* Мәкаль

**ТӨБЕ́-ТАМЫРЫ** *и.* 1) Барлыгы, нигезе, асылы. *Аны йөзеп чыгар өчен, суда батмастай, утта янмастай бозваткычлар белән кораллану, һәрбер мәсьәләнең, һәрбер күренешнең төбентамырын ачып күрсәткән таза акыллы кеше булырга кирәк.* Г.Кутуй. *Хәсәнов үзенә бер ысул белән гаять көчле нәтиҗәгә ирешә: илдәге, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрнең асылын күрсәтә, төпле анализ ясый, бигрәк тә бүгенге армиядәге тәртипсезлекләрнең төбен-тамырын ачып сала.* Р.Сверигин

2) Барлык яклары, барлык ваклыклары. *[Рус телен] ул кадәрле үк төбеннән-тамырыннан белмим бит әле.* Г.Бәширов

◊ **Төбеннән-тамырыннан йолку** *к.* **төбе-тамыры белән йолку**. **Төбе-тамыры белән** Бөтенләй, тулысынча, беткәнче. – *Син бит бүгенге җәмгыятьне төбе-тамыры белән актарасың, яраксызга әйләндереп, сүтеп ташлыйсың, – дип очып-очып кунды ул Ирекkә.* Ф.Садриев. *Сугыш безнең гаиләне әнә шулай төбе-тамыры белән тузгытып ташлады.* М.Әмирханов. **Төбе-тамыры белән йолку** Бөтенләй бетерү, эзен дә калдырмыйча, тулысынча юк итү. *Хәзер анда яшәгән халык хәтереннән ханлык дигән сүзне һәм бу идеяне төбе-тамыры белән йолкып ату, үткән тарихны оныттыру кирәк.* В.Имамов

**ТӨ́БӨЙГЕЧ** *и.* Үсемлекләрнең төпләрен, тамыр тирәсен йомшарту, төбенә балчык өю өчен махсус авыл хуҗалыгы агрегаты; *русчасы*: **окучник**. *Хуҗалыкка яңа төбөйгечләр алынды*

**ТӨГӘЛ** *с.* **1.** 1) Дөрес, чынбарлыкка тулысынча туры килгән; билгеле тәгъбиргә, санга һ.б.ш.га тәңгәл; артык та, ким дә түгел. *Ләкин мин ачык хәтерлим: «Маяк» радиостанциясе әле генә төгәл вакыт сигналын биргән иде, менә хәзер ул аны яңадан кабатлап маташа.* А.Тимергалин. *Соры Күсе шартлаткыч патроннарны Таһирга үзенчә бик төгәл исәп белән бирә.* А.Хәсәнов

2) Берәр нәрсәне бик дөрес, бик вак берәмлекләренә кадәр күрсәтә торган. *Башкарылган эшне тикшергәндә, рентген һәм тагын башка төрле төгәл приборлар кулланыла...* М.Хәсәнов. *Француз Серж Арош һәм америкалы Дэвид Вайнлэнд казанышлары ярдәмендә киләчәктә дөньядагы үтә төгәл сәгать --- ясап булачак.* Өмет

3) Җентекле, конкрет, тулы, анык, сораулар тудырмаслык. *Экспертлар төркеменең сорауларын алыгыз да барысына да төгәл җавап язып бирегез!* З.Зәйнуллин. *Шулай да, берәр гадәттән тыш хәл килеп чыкса, аңа төгәл инструкция бирелгән...* Шәһри Казан

4) Төгәллек, тәртип ярата торган, теләсә нинди эшне үз вакытында, җиренә җиткереп, җентекләп үтәүчән. *Шаккаталар: төгәл егет, төгәл шагыйрь... чамалы!* К.Сибгатуллин. *Әгәр пөхтәләп тиешле урынга урнаштырса, ул – исәп-хисап ярата торган төгәл кеше.* Р.Гарифуллин

5) Математикага нигезләнгән (фәннәр тур.). *Менә шушында Фәтхулла хәзрәткә төгәл фәннәргә яшьтән үк ифрат сәләтле булуы ярдәмгә килде.* А.Тимергалин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Дөрес итеп, таләпләргә, үлчәмгә һ.б.ш.ларга тулысынча

туры китереп. *Кабызу системасына өр-яңа конденсатор куйды, шәмдәге «чаткы аралыгы» дигән нәрсәне бик төгәл үлчәде, контактларны ялтыраганчы чистартты, гайкаларны яхшылап тарттырды.* А.Тимергалин. *Аның һәр эше төгәл үлчәнгән.* Р.Сафин

2) Тулысынча, барлык нечкәлекләре белән, яхшылап, анык рәвештә. *Университет, кафедра сүзләрен аның элек тә ишеткәне бар иде, тик менә аларның мәгънәләрен генә төгәл аңлап җитми иде.* Н.Фәттах. *Аның эчтәлеген әле яңа гына танышкан ят мөсафирга унбиш-егерме минут эчендә тәмам ачып бетерү, әлбәттә, мөмкин түгел, җитмәсә, төрек теленең фәнни атамаларын төгәл төшенү, аларны шундук татарчага әйләндереп кәгазьгә теркәү үземә дә бик кыен эш иде.* Т.Әйди

3) Вакытында, соңга калмыйча, нәкъ билгеләнгән вакытта. *Рәмзия эшкә төгәл йөри, сигез тулыр алдыннан кибетенең зәңгәр ишекләре киереп ачып куела.* Н.Әхмәдиев. *Төнге уннан калганы юк, Аллага шөкер, лекцияләренә дә төгәл йөри.* Ф.Садриев

4) *мат.* Калдыксыз (бүленү тур.). *Шуннан йөз илле меңне утыз алты меңгә бүләбез. Төгәл бүленми.* Э.Шәрифуллина. *Сиксән сигез икегә төгәл бүленә ул.* К.Кәримов

**3.** *хәб. функ.* Җитеш, мул; кимчелекле түгел. *Йортыбыз-җиребез хәзергә төгәл. Узган-барганнардан акмаса да тама.* Ш.Камал

**4.** *кис. функ.* Нәкъ, тач; артык та түгел, ким дә түгел; тулы. *Аннан соң Ялта, Феодосия һәм Керчь шәһәрләре аша үтеп, 17 мартта Сухумига килеп җитә, жандарм идарәсе мәгълүматларына һәм «Йолдыз» газетасында басылган хәбәрләргә караганда, ул анда төгәл дүрт ай тора.* М.Хәсәнов. *Ә ул киткәч, төгәл ике-өч көн үткәч, шәһәр артындагы бакчама киттем.* Ф.Баттал

**ТӨГӘЛЛӘМӘ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең иң соңгы, иң ахыргы өлеше. *Кульязма китапның төгәлләмәсе. Эшнең төгәлләмәсе*

2) Нәрсәне дә булса киңрәк ача, төгәллек бирә, ачыклык кертә торган нечкәлек, деталь, мәгънә төсмере һ.б.ш. *Шулай ук бу төрдәшләрдә мәкальләрнең тарихи эволюциясен күрсәтә торган кызыклы төгәлләмәләр дә очрый.* Н.Исәнбәт

**ТӨГӘЛЛӘНЕШ** *и.* 1) Бөтенлек, тулылык, камиллек. *Чигүле милли сөлге композициягә төгәлләнеш бирә шикелле.* Д.Садыйкова

2) *әд.* Әдәбият, кинематография һәм сәхнә әсәрләрендә конфликт хәл ителгән, вакыйгалар тәмамланган өлеш; йомгаклау өлеше. *Әмма бу төгәлләнеш тулы әсәрнең аһәңенә һәм мәгънәсенә буйсынулы килә, аның бер өлеше, компоненты рәвешендә кабул ителә.* Х.Миңнегулов. *«Сугыш һәм солых», «Тын Дон» эпопеяларында ситуация үзенең төгәлләнешен тапмаганмыни?* Ф.Хатипов

**ТӨГӘЛЛӘНҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төгәлләү** I. *Эш төгәлләнү*

2) Тулысынча бетү, тәмамлану, ахырга кадәр җитү. *Җыр төгәлләнүгә, уртага ефәк япмалар бөркәнгән чибәр туташлар чыкты.* М.Әмирханов. *Озакка сузылган ул мәшәкатьле эш төгәлләнгәннән соң, шуны күрдек: республика һәм район матбугатларында актив катнашып, әсәрләрен бастырып килүче яшь һәм башлап язучылар саны 800 дән артып китә икән!* М.Вәлиев

3) Тиешле таләпләргә җавап бирерлек, төзек, дөрес хәлгә килү; тәмамлану. *Җөмләләр төгәлләнмәгән, сүзләре ярты-йорты калган битләр бар.* Л.Ихсанова. *Шагыйрьләрне Дәрдемәнднең поэтик осталыгы, тар мәйданда төгәлләнгән фикер, аз сүз белән тирән мәгънә ачу сәләте, тулпар ат, кучкар образлары, мәләк, талчыбык һ.б. магнит кыры кебек, үзенә тартып тора.* Т.Галиуллин

4) *сөйл.* Өмет, теләк һ.б.ш.лар гамәлгә ашу, җиренә җитү, күңел түгәрәкләнү. *Төгәлләнде, егет, теләгем: Таһир – Зөһрәләрне бер күрергә Ашкына иде күптән йөрәгем.* Ф. Бурнаш

5) *күч.* Тотылып, сарыф ителеп бетү. *– Акча төгәлләнгән чакка туры киләсең син һаман, – диде ул елмаеп.* Сөембикә

6) *күч.* Бөтәю, бөтенләнү, рәтләнү, канәгатьләнерлек дәрәҗәгә җитү, җайлану. *Аягым төзәлде, өс-баш төгәлләнде, тәмам кеше булдым.* Г.Толымбай

**Төгәлләнә бару** Бер-бер артлы төгәлләнү. *Поэзиябезгә килүче яшьләребез арасында һаман да ачыла, үсә, төгәлләнә баруы белән сокландыра да, шатландыра да ул мине.* Х.Туфан. *Ярышлар бер-бер артлы төгәлләнә барды, берара бөтен халык урыныннан кузгалып, шаулашып, атлар чабышын карады.* М.Маликова

**Төгәлләнеп бару** Әкренләп төгәлләнү, төгәлләнергә күп калмау. *Аның ишегалдында тугыз гөмбәзле ике йөз метр биеклектәге чиркәүне алтын белән тышлау эшләре дә төгәлләнеп бара.* Ф.Баттал

**Төгәлләнеп бетү** Тәмам төгәлләнү. *Айратның төгәлләнеп бетмәгән хикәясен Фәрит бер тын белән укып чыкты.* Ш.Алпар. *Аның эше төгәлләнеп бетмәгән иде.* М.Кәбиров

**Төгәлләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә төгәлләнү. *Бердән, редакцияләү эшеннән бушап булмый, икенчедән, фабула, сюжет корылмасы һаман да әле төгәлләнеп җитми.* Г.Бәширов. --- *мөселманнар, элек ясаган хаталарыннан арынган тәкъдирдә, уңышка ирешәчәкләр, чөнки рус инкыйлабы әле төгәлләнеп җитмәгән.* Безнең мирас

**Төгәлләнеп килү** Соңгы арада төгәлләнүгә таба бару. *Шүрәле инде төгәлләнеп килә, аңа йонлач кием кидертәсе генә калды.* А.Тимергалин. *Урыпҗыю эшләре төгәлләнеп килә, көзге чәчүгә чыгарга әзерләнеп йөри идек.* В.Нуруллин

**Төгәлләнеп кую** Төгәлләнгән хәлгә килү; тиз арада төгәлләнү. *Хәтта «Көтелмәгән һөҗүм» дигән хикәясе дә, шактый шомлы сурәтләр белән башланып китеп, эчкә шик-шөбһә йөгертсә дә, күңелле генә төгәлләнеп куя.* А.Мансуров

**ТӨГӘЛЛӘНҮ** II *ф. төш. юн. к.* **төгәлләү** II. *Хәзерге вакытта шагыйрь биографиясенә, иҗатына караган яңа фактлар ачыла, детальләр төгәлләнә.* М.Шәрипов

**ТӨГӘЛЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Нинди дә булса эшне тулысынча тәмамлау, ахырына кадәр башкарып чыгу. *Институтны төгәлләгәч, тынычрак җиргә җибәрүләрен сорадым.* А.Тимергалин. *Укы-*

*тучының үз кайгысы кайгы: мәктәпкә тикшерү килергә җыена, бөтен кәгазьләрне тәртипкә китерергә, сыйныф журналын кабаттан күчереп язарга, электрон көндәлекне тутырырга – кыскасы, очы-кырые күренмәгән эшләрне төгәлләргә кирәк иде.* А.Әхмәтгалиева

2) Моңарчы булганга тагын нәрсәдер өстәп, тулырак итү, тулыландыру. *Әлеге ике персонаж бер-берен төгәлли дип саныйм.* Мәйдан

3) Канәгатьләнерлек хәлгә китерү, җиренә җиткерү. *Сурәтне төгәлләү өчен шуны гына өстисе кала.* Ә.Баян

4) *күч.* Тулысынча кулланып, бер дә калдырмый тотып, сарыф итеп бетерү. *Ул кичә капкадан чыгу белән кемнәргәдер очраган да, бергә-бергә шунда акчаны төгәлләгәннәр.* Г.Ибраһимов. *Балалар шулай итеп итне төгәлләп кенә торалар икән.* Г.Рәхим

**Төгәлләп бетерү** Барысын да төгәлләү, тулысынча төгәлләү. *Эшне төгәлләп бетерә алмавымда минем гаебем юк, моны бер син генә беләсең.* М.Маликова. *Пьесасын тулысынча төгәлләп бетерде, повестенең соңгы битләренә якынлашты.* Ф.Садриев

**Төгәлләп җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә төгәлләү. *Бу эшне коллектив кризис вакытында җиңеп чыга: төзүчеләр төгәлләп җиткермәгәнне әти-әниләр һәм укучылар белән дәррәү кубып эшләп куялар.* Өмет

**Төгәлләп килү** Соңгы вакытта әкренләп төгәлләү, төгәлләүгә таба бару. *Юкка шатланганбыз икән: чаманы белми яшь автор, романның инде утызынчы бүлеген төгәлләп килә, әмма ахыры һаман күренми.* З.Мәхмүди. *Ишегалдында эшләрен төгәлләп килгән Наташаның сүзләре дә колагына чалынып кына калды: – Ичмасам, башыңа ки!* А.Мансуров

**Төгәлләп кую** Төгәлләнгән хәлгә җиткерү; тиз генә төгәлләү. *Уйланып торгандай итте дә фәлсәфи йомгагын хәйләкәр генә төгәлләп куйды: – Өйләндем, диярсең.* Т.Галиуллин. *Хастаханәдән чыгуга ук, әлеге төшне язып калу өчен, чираттагы ялымны алдым да, тулыр-тулмас бер ай эчендә, баш күтәрми эшләп дигәндәй, Сабан туена да барып йөрмәстән, өч йөз битле ярымфантастик романның караламасын төгәлләп куйдым.* Ш.Алпар

**Төгәлләп тору** Хәзерге вакытта төгәлләү; төгәлләнгән күренеш тудыру; төгәлләү алдында булу; вакытлыча төгәлләү. *Ә бинаны өске яктан төгәлләп тору өчен, сәнгать алиһәләренең сыннарын, милли һәм заманча фикерләүгә корылган матур-матур фигураларны файдаландылар.* М.Вәлиев. *Алайса бу сөйләшүне төгәлләп торыйк, калганын икенче очрашкач хәл итеп бетербез.* Н.Хәсәнов

**Төгәлләп чыгу** Барысын да берәмберәм төгәлләү. *Изге эшне төгәлләп чыгарга Аллаһ үзе көч бирде.* Г.Әдһәм. *Тоташтан төгәлләп чыкмагач, ике-өч тапкыр мәшәкатьләрәк булачак хәзер.* К.Кәримов

**Төгәлләп яту** *сөйл. к.* **төгәлләп тору**. *Быел ул роман төгәлләп ята.* Ф.Яруллин. *Ләхетне ялгызы алып, шуны төгәлләп ятышы.* Ватаным Татарстан

**Төгәлли язу** Чак кына төгәлләми калу. *Көлергә дә, еларга белмәссең дигәндәй, малай таныш репертуарны төгәлли язганда гына, Ильяс кычкырып көлеп җибәрде: – Һәйт, менә ичмасам җырчы! Менә рәхмәт. Миннән дә уздырдың, егет икәнсең.* Ә.Баян

**ТӨГӘЛЛӘ́Ү** II *ф.* Төгәл итү, дөресләү, турылау, аныклау. *Ваһапов, орудие калканына ябышып прицелны төгәлләгәч, сугышчыга: – Рычагны тарт!* Х.Камалов

**ТӨГӘЛЛӘҮЛЕ** *с. лингв.* Ияртүче сүз яки җөмләдән аңлашылган мәгънәне шуңа охшаган башка төшенчәләрдән аерып, конкретлаштырып килә торган; ачыклаулы. *Кайчак иярүче сүз кабатланып килгәндә генә, сүзләр төгәлләүле мөнәсәбәткә керергә мөмкиннәр.* Р.Сәгъдиева. *Шуны да әйтергә кирәк, иярткүле бәйләнешкә кергән сүзләр, сөйләм оештырудагы әһәмиятләренә карап, үзара өч төрле мөнәсәбәттә булырга мөмкин: хәбәрлекле, төгәлләүле, аныклаулы мөнәсәбәтләр.* З.Кәримова

**ТӨГӘЛЛЕК** *и.* 1) Тулылык, төгәлләнгәнлек, камиллек. *Нинди камиллек, төгәллек бар гаҗәеп зур планеталар, йолдызлар берлегендә!..* А.Гыйләҗев

2) Исәпләү, үлчәү һ.б.ш.ларда дөреслек; читкә китеш, ялгышлар булмау күренеше. *Ары таба синең кебек төгәллек яратучылар игътибарына санап та күрсәтелә: ике-өч хуҗалыкка бер ат һәм бер сыер, бер хуҗалыкка икешәр сарык һәм ким дәрәҗәдә кирәк булган авыл хуҗалыгы кораллары калдырыла.* М.Хуҗин

3) Эш итүдә пөхтәлек, пунктуальлек. *Фән эше төгәллек таләп итә*

**ТӨГӘЛЛЕКСЕЗ** *с.* **1.** Төгәл булмаган, тулы булмаган. *Төгәллексез исемлек*

**2.** *рәв. мәгъ.* Якынча, төгәл түгел. *Максат-бурычлар төгәллексез билгеләнгән.* Ялкын

**ТӨГӘЛСЕЗЛЕК** *и.* 1) Берәр эштә җибәрелгән хата, җитешсезлек, ялгыш. *Иҗатында бәләкәй генә хата, төгәлсезлек китүдән – иҗатка хыянәт итүдән калтыранып курка иде Фаил.* М.Хуҗин. *Кайсы мәкаләнең теле начар, икенчесенең темасы актуаль түгел, укучы хатлары аз бирелгән, фәләненче биттә хәреф хатасы яисә ниндидер бер зур төгәлсезлек киткән, фәлән материалга бирелгән рәсем уңышлы булмаган.* Р.Миңнуллин

2) Берәр эшнең үтәлешендә төгәллек булмау, эзлеклелек, системалылык җитмәү. *Ләкин халыкны исәпкә алуның бу төрләренә төрле дәрәҗәдә кимчелекләр, төгәлсезлекләр хас булган.* Г.Исхакый. *Шәһәр кремльләрендә авышлык, төгәлсезлек булырга мөмкин, ә монда юк!* Р.Газиз

3) Кеше характерында, гадәтендә төгәллек, пунктуальлек, пөхтәлек җитмәү күренеше. *Еш кына энем Искәндәр белән безгә төгәлсезлегебез өчен эләккәләде дә.* Ватаным Татарстан

**ТӨГӘНМӘС** *с. к.* **төкәнмәс**. *Ялгыз, үзенең иҗтиһады, төгәнмәс дәрте белән теләгенә, хөрмәтле дәрәҗәсенә ирешкән татар хатыны ул.* Б.Урманче. *Бетмәгән шикелле кояшның яктысы, Аналар җылысы йөрәктә төгәнмәс ---.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ТӨГӘНҮ** *ф. иск.* 1) *к.* **төкәнү**. *Явыз кулның сихри куәте төгәнде.* Г.Ибраһимов. *Шуңа күрә сабырларым тәмам төгәнде.* Г.Камал

2) Ябыгу, бетәшү. *Төгәнгән әбекәй*

**ТӨЕК** *и. сир.* **1.** Төелгән, бик нык вакланган нәрсә. *Тоз төеге*

**2.** *с. мәгъ.* Төелеп, бик ваклангып беткән. *Сынмады бер нәстә дә. Төек бар да.* З.Зәйнуллин

**ТӨЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төю**. *Теш порошогы кебек йомшак итеп төелгән, төсе сап-сары.* Ф.Сафиуллин. *Башыма киледә төелгән пыяла, аякларыма дыңгычлап арыш саламы тутырганнар диярсең!* Т.Галиуллин

2) Тамакка коры азык һ.б.ш. тыгылудан буылу, тын бетү. *Син аңа әйтергә иде, сыер комсыз бит ул, кайчагында бәрәңге белән дә төелеп үлә, дияргә иде.* Т.Гыйззәт. *Ашыккан эт төеләдер.* К.Тинчурин

3) *күч.* Елыйсы яки көләсе килеп тә, бик нык әсәрләнүдән, тәэсирләнүдән елый, көлә алмый тору. *Кыз яшенә төелде, ике кулы белән битен каплады.* Р.Камал. *Мондый гамәлләр Аллаһы Тәгаләнең кодрәтеннән башка кылына алмаса да: «Син безнең якын кешебезне үлемнән алып калдың», – дип, яшькә төелүче дә булды.* З.Фәйзрахманова

4) *күч.* Әйтәсе, сөйлисе килгәндә комачаулау, сөйли алмый тору, сөйләүдән тукталу. *Ул, тамагы төелеп, эндәшә алмыйча торды...* А.Хәлим. *Курку, җирәнү, нәфрәтләнү тойгылары, бергә кушылып, Һәдиянең тамагына төелде, ул, төенне төкерим дип, авызын ачты, ачыргаланып кыргый аваз чыгарды һәм уянып китте.* Г.Якупова

**Төелеп бетү** Тулысынча төелү, тәмам төелү, бик нык төелү. *Ашый-ашый төелеп бетте, әмма сер бирмәде ---.* Р.Вәлиев

**Төелеп житү** Тиешле дәрәҗәгә кадәр төелү, тәмам төелгән хәлгә килү. *– Тагын бераз төергә кирәк әле, төелеп җитмәгән бит бу, – дип, безнең эшне тикшерде дә бәрәңге чистартуын дәвам итте әни.* А.Вәлиева

**Төелеп кую** Алдан төелү. *Борыч алдан төелеп куелган иде, без аны кечкенә пыяла савытларга тутырдык.* Сөембикә

**ТӨЕН** *и.* 1) Җеп, бау, яулык һ.б.ш.ларда бәйләнгән, төйнәлгән урын; озын нәзек әйберләрнең элмәк сыман итеп тарттырылып төйнәлгән өлеше. *Беренчесендә, сихер догасын укып, бау яки җепкә төеннәр ясаганнар, ә икенчесендә дога укып әфсенләнгән тоз-борыч кебек тәмләткечләрне яки башка бер ризыкны кешенең ашына кушып биргәннәр.* А.Тимергалин. *Төенләнгән төеннәрне ничек итеп чишәргә дә белмим.* А.Нәҗми

2) Яулык, тукыма һ.б.ш.ларның эченә берәр кирәк-ярак салынып, очочлары бергә бәйләнгән әйбер. *Култык астына төен кыстырып, Гамилә үтеп бара.* Т.Гыйззәт. *Тугры ярдәмчеләр, җан сакчылары белән бергәләп, сәгатеминуты белән көчәйгән явыз уттан башта министрны түгел, салонвагонга шыплап тутырылган кыйммәтле бүләкләрне – сандыкларны, чемоданнарны, бөктәрләрне, төеннәрне алып чыкканнар икән!* А.Гыйләҗев

3) Бер урыннан икенче урынга күченү сәбәпле, төрле сумка, чемодан, пакет һ.б.ш.ларга тутырылган әйберләр. *Ике ай төеннәр өстендә утырдык.* А.Гыйләҗев. --- *әйберләребез дә кайсы кая таралышып ята. Тегендә дә, монда да төеннәр өстендә яшибез.* К.Тимбикова

4) Юлчының шәхси әйберләре, янында булган багажы. *Тимеркәй төенен тотып чыгып китә.* Т.Гыйззәт

5) Төрле яктан килгән юллар яки башка элемтә чаралары тоташкан, кисешкән җир, шуларның мөһим ноктасы. *Иң кирәкле тимер юл төене безнең кулда.* К.Нәҗми. *Десантчылар тәэминат базаларын һәм элемтә төеннәрен тар-мар иттеләр.* С.Баттал

6) *биол.* Организмда теге яки бу күзәнәкләр, кан тамырлары күп булган урын. *Үзәк нерв системасына йокылык өсте нерв төене – баш мие, йокылык асты нерв төене, парлы нерв төеннәреннән – ганглийлардан торган корсак нерв чылбыры керә.* Биология. *Тәнендә сөялләр, тамыр төеннәре дә, төкле шадралар да күренми.* К.Кәримов

7) Җимеш яралгысы, төймә, бәбәк. *– Чәчәкләре коелгач, кечкенә төеннәр күренә башлар, өшемәсеннәр генә, – диде бабасы ---.* Мәйдан

8) *физ.* Электр чылбырының берничә тармагы тоташкан нокта

9) *физ.* Торгын дулкыннарда кинетик яки потенциаль энергия нульгә тигез булган нокталарның һәрберсе

10) *мат.* Дифференциаль тигезләмәнең үзенчәлекле нокталарыннан бер төре

11) *күч.* Вакыйгалар, эш-хәлләр, үзара мөнәсәбәтләрнең катлаулы һәм каршылыклы моменты. *Чыннан да, нинди генә четерекле хәлләр килеп чыкмаган да, нинди генә төеннәр чишелмәгән.* Н.Акмал. *Иң катлаулы тормыш төеннәрен чишкәндә, аның иң ышанычлы, турылыклы юлдашы – юмор.* Ватаным Татарстан

12) *күч.* Күңелдә калган авыр рәнҗү, канәгатьсезлек хисе; кемгә дә булса күңелдә сакланган үпкә, нөктә. *Шундый күңелле кичләрдән соң тәннәре язылып, күңелдәге төен таралып киткәндәй тоела иде аларга.* К.Кара. *Әтием-әнием турындагы истәлекләр йөрәгемдә төен булып калды.* А.Мансуров

13) *күч.* Дулкынлану, курку кебек психофизик халәттә барлыкка килә, суларга, сөйләшергә һ.б.ш.ларга комачаулый торган спазм. *Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам.* Г.Кутуй. *Бугазына тыгылган төенне авырттырып йотып җибәргәндә, ике «юл», битне юешләп, түбән сузылды.* Г.Әдһәм

**ТӨЕНЛӘНЕШ** *и. әд.* Әдәби әсәрдә конфликт үсешенә китерерлек төп вакыйгалар башланып китә торган өлеш. *М.Гафуриның «Кара йөзләр» повестенда төенләнеш кинәт башланып китә, һәм каршылыклар, бик тиз кискенләшеп, иң киеренке ноктасына җитә.* Ф.Хатипов. *Гөлзифаның пот ярым бодай мәсьәләсен тыңлап тору вакыйгасы сюжет сызыгында төенләнеш булып тора.* Г.Гайнуллина

**ТӨЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төенләү**. *– Кызым үскән бу юлы, – диде карчык һәм, кесәсеннән чыгарып, төенләнгән кульъяулыгын чишә башлады.* Ф.Җамалетдинова. *Куллар үзеннән-үзе төенләнгән бавын чиште, аннары бармаклары гармун телләренә кагылды.* Г.Әдһәмова

2) Йомарлану. *Йодрыклары каты төенләнгән, Күкрәк киерелгән, йөз кы-*

*рыс ---.* Р.Вәлиева. *Ихтыярсыздан авыр йодрыклары төенләнде.* Ш.Шәйдуллин

3) *әд.* Әдәби һ.б. әсәрдәге вакыйгалар үсешендә конфликт барлыкка килү, киеренкелек башлану. *Әсәр атамасының мәгънәсе сюжетның төенләнү мизгелләрен үз эченә ала.* М.Хәбетдинова

4) *күч.* Барлыкка килү, туу, оешу, формалашу. *Минем сүзләргә әз генә ышанычы төенләнә башлады шикелле.* Х.Камалов

5) *күч.* Эш-хәлнең үтәлеше нәрсәгә дә булса бәйле булу, шуңа барып тоташу. *Нәрсә генә сөйләсә дә, сүзе бер нәрсәгә килеп төенләнә иде.* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Бәйләнеш барлыкка килү, очрашу, кисешү. *Әмма язмышыбыз җепләре барыбер Мәскәүдә төенләнде.* Кызыл таң

7) *күч.* Төрле уй-фикерләр, тойгылар күңелдә авыр йөк булып җыйналу, туплану. *Ә уртага салып сөйләр сүзе, төен булып төенләнгән ризасызлыгы җитәрлек иде.* А.Вергазов. *Бер көндә түгел, елларга бүленсә дә, кайгыхәсрәт барыбер төенләнеп, бер йөрәк аша уза икән.* Р.Вәлиев

**Төенләнә бару** Эзлекле рәвештә берәм-берәм төенләнү. *Хәзер инде хатирә-истәлекләр күңелдә төенләнә бара.* М.Галиев

**Төенләнә башлау** Төенләнергә керешү; төен барлыкка килү. *Шуның белән ике яшь йөрәк арасында төенләнә башлаган язмыш җебе өзелде.* Г.Гыйльманов

**Төенләнә төшү** Бераз төенләнү; тагын да ныграк төенләнү. *Аның йөзе кырыслана, йодрыклары төенләнә төште, әмма тыңлавын дәвам итте.* Р.Вәлиева

**Төенләнеп бетү** Бик нык төенләнү, тәмам төенләнү. *Икенчесе төенләнеп беткән иске чыбыркысы белән атка сугып алды.* М.Галәү. *Мөнәсәбәтләр чуалып, чәбәләнеп, төенләнеп беткән.* Х.Камалов

**Төенләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә төенләнү; тәмам төенләнү. *Әле ул поэтик фикер булып төенләнеп җитмәгән.* Ш.Галиев

**Төенләнеп калу** Ниндидер вакыйгадан соң төенләнү, төенләнгән хәлгә килү. *Берни түгел, Шунысы авыр: Төенләнеп калса сүзләрең, Үтәлгәне түгел, үкенечле Үтәлмичә калган эшләрең.* К.Вәлиди

**Төенләнеп килү** Төенләнү алдында тору. *Ниндидер эчке өнәмәү төенләнеп килә.* Х.Камалов. *Димәк, бу фикер – очраклы рәвештә әйтелгән эффектлы тәгъбир генә түгел, ә халык күңелендә төенләнеп килә торган фикер.* Р.Фәйзуллин

**Төенләнеп китү** Төенләнгән хәлгә килү, соңгы вакытта төенләнү. *Коллизия болай төенләнеп китә.* Ф.Хатипов

**Төенләнеп тору** Төенләнгән торышта булу, төен рәвешендә булу. *Шуңа күрә ул кулы, сугарга әзерләнгән төсле, һәрвакыт йодрыкка төенләнеп тора.* Г.Галиев

**ТӨЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Җеп, бау кебек озын, сыгылмалы нәрсәләрнең очларын бәйләп, төен ясау, төен хәленә китерү. *Аллаяров соңгы җеп очларын төенләде.* С.Сөләйманова. *Эш беткәч, әнисе җепләрнең барысын бергә җыеп төенләде дә станның алгы агачына беркетеп куйды.* Д.Каюмова // Җеп, бау, аркан кебекләрдә элмәкләп тарттырып төен ясау. *Энәне саплаганнан соң, җепнең очын төенләү*

2) *к.* **төйнәү** (*2–3 мәгъ.*). *Әтәч мондый борылышны көтмәгән иде, йодрыкларын төенләп, Маликка таба бара башлады.* М.Хәсәнов. *Сәрмән өй эченә күз йөртеп чыкты: бөтен нәрсә тарау ята, бер дә җыеп төенләгәнгә охшамаган иде.* М.Галиев

3) *күч.* Тәмамлау, бетерү, төгәлләү. *– Моны син электән белергә тиеш идең, – дип, вәгазь белән сүзен төенләр.* Ф.Яхин

4) *күч.* Җыю. *Ниндидер кыргый көч, бар уй-фикерләрен төенләп, көннән-көн көчәеп, күңелен кимерде.* Н.Гариф

◊ **Төенләп кую** Нык хәтерләү; күңелгә салу, колакка киртләү. *Шөреп күңеленә төенләп куйды: пахан – хәйләкәр төлке, аның белән сак булырга, итәкне җыеп йөрергә, иң якын дустыңа да сереңне ачмаска.* Т.Галиуллин

**Төенләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча төенләү. *Сырхау еллардан ук ябышып калган чире йолкыганда, ирексездән җаны талкынганда, җанына җылы бирәсе урында, күпләр (ятлар гына да түгел!), ялган белән дөреслекне шулкадәр чишәлмәслек төенләп бетереп, бәгырен теләләр иде.* К.Сибгатуллин. *--- кем әйтмешли, соңгы җөйне төенләп бетергәнен дә көтмичә, модельерларның кулыннан тартып алып, өр-яңа үрнәкләргә төренеп сәхнәгә дә чыгып өлгерә.* К.Кәримов

**Төенләп кую** Алдан яки тиз арада төенләү. *Кәримә апа әби белән өйдәге әйберләрне төенләп куярга өлгергәннәр.* Н.Хәсәнов

**Төенләп тору** Һәрвакыт, гел төенләү. *Ә Болак хәтерли барысын: Төенләп торганнар шул алар Уң Болак – Сул Болак арасын.* С.Әхмәтҗанова

**Төенләп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы төенләү. *Беркөнне, йөри торгач, яулыгымның дүрт читен дә төенләп чыкканмын.* Ш.Галиев. *Базардан ашыгып кайткан Хәкимулла, үзе төенләп чыккан төеннәрнең таратылып ташланганын вә картның һаман әле чәйшикәр белән булышканын күргәч, аптырап китте.* Ватаным Татарстан

**ТӨЕНЛЕ** *с.* 1) Төене булган. *Кояшяңгырдан уңып беткән кырык төенле кер бавында җилләтергә соңгы елларда нибары шул зәңгәр күлмәк кенә калды.* А.Гыйләҗев. *Сездә генә бит ул төенле дилбегә.* Н.Кәримова

2) *күч.* Бик катлаулы, буталчык. *Аны белгәндә, төенле серләр тиз чишелер иде.* Н.Хәким

**ТӨЕНЧЕК** *и.* 1) Кечерәк төен (*2 мәгъ.*). *Әни белән Садыйка түти, кырыккан йоннарын төенчеккә төйнәп, төенчекләрен баш өсләренә куйганнар да бездән бераз гына алдан баралар.* А.Хәлим. *Хәтирә апа Тансык кулына бер төенчек тоттырды.* З.Зәйнуллин

2) Төенгә (*2 мәгъ.*) охшаган берәр нәрсә. *Шулар арасыннан, ямьсез тавыш белән акырып, яман пошкырып, мендәр хәтле ут төенчеге атылып чыкты.* Г.Бәширов

**ТӨЕР** *и.* **1.** 1) Гадәттә йомшак яки көпшәк матдәнең тыгызланган һәм бераз йомрыланган кисәге; оешкан каты масса кисәге. *Аның кечкенә агач калагы тиз-тиз хәрәкәтләнә, ә төрәнгә*

*ябышкан туфрак төерләре әллә кая очалар.* Г.Әпсәләмов

2) Сыек яки сеңәлсыман кебек масса эчендәге тыгыз, каты кисәкчә. *Камырны, йомшак (каймак камырыннан куерак), ләкин кашыктан агып төшмәслек итеп һәм төерләр калдырмыйча, кашык белән яхшылап изәләр.* Казан утлары. *Бәрәңгене әрчеп, юып, тозлы суда пешерәләр, суын агызып, төерләр калмаслык итеп төяләр, кайнар сөт, йомырка салалар, тоз өстиләр.* Минем йорт

3) Тәннең йомшак өлешендә кечкенә түгәрәк каты шеш. *Прополис, бал, атланмайдан бәлзәм-крем ясаттырып алып, буыннарындагы шеш төерләренә шуны сылый башлады.* Д.Булатова. *Көн дә мунча ягабыз, апа тәнемне уа, күкрәгемдәге төерләр инде бетеп килә, дигән.* З.Мәхмүди

4) Үсемлектә, гадәттә агач кәүсәсендә үсеп чыккан каты оры. *Кәүсәсендә мендәр хәтле түгәрәк төере булган куш каен янына җиттек.* Г.Мөхәммәтшин

5) Ир-атның бугазында бераз алга таба калкып торган кимерчәктән гыйбарәт чыгынты; бугаз төене, тамак алмасы. *Аның авыз читеннән, чүмеч төбеннән пыяладай ялтырап торган салкын тамчылар тамды, йоткан саен, бугаз төере кыймылдап торды.* Н.Фәттах. *Кешенең яңак мускуллары йөри, иреннәре мелт-мелт килә, бугаз төере менә-төшә.* Р.Харрасова

6) *анат.* Организмда бер үк төрле функция башкара торган нинди дә булса күзәнәкләрнең җыелган, кушылган урыны. *Никотин нерв төерләренә дә (бигрәк тә вегетатив нерв төерләренә) тәэсир итә.* Агулы үсемлекләр

7) *күч.* Күңелдә, йөрәктә калган һәртөрле авыр хис-тойгы. *Күңелеңдә төерләр булган килеш яшәве дә кыен бит, Гөлниса.* М.Хуҗин. *Шул вакыйгадан соң тулы бер халыкка карата ышанмаучанлык төере калды йөрәгендә.* Т.Галиуллин

8) *күч.* Дулкынландыргыч мизгелләрдә сүз башларга, сөйләргә комачаулап, тамак турысында барлыкка килгән дискомфорт; борчып тора торган авырлык. *Сүз башламакчы гына булам, бугазыма утлы төер килеп тыгыла.* А.Гыйләҗев. *Саубуллашканда, Айбиби еламады, түзде, хәзер исә, юлга чыккач, ат теркелдәп юыртканда, күчәрбаш йокымсырап баргангамы, тамагына яшь төере килеп өелде.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Тупас, усал, дорфа. *Холкыфигыле белән Гәрәй элекке Гәрәй булып кала. Шул ук кырыс йөз, җанга якын сүзләрне оныткан төер тел.* Г.Мөхәммәтшин

**ТӨЕРЕМ** *с.* **1.** 1) Калын, юан. *Хакимият башлыгы, төерем иреннәрен җәеп, кычкырып көлеп җибәрде.* Т.Галиуллин

2) Тигезсез, калынлы-нечкәле. *Җебең төерем, тигез эрләнмәгән*

3) Юан, тулы гәүдәле. *Аяз күктә төерем кош бер сайрый, бер кыйлана, Безнең Айдар абзамызга дан җырлап суфилана.* Җ.Дәрзаман. *Уймак кебек төерем, кечкенә буйлы, кара бөрлегән кебек кара күзле бу кыз минем сабый чак «мәхәббәтләремнең» соңгысы булган кебек.* А.Хәлим

**2.** *и. мәгъ.* Төер (*1 мәгъ.*), кантар. *Ниһаять, ул күзенә чалынган туфрак төеремен кулына эләктерде һәм бөркеткә атты.* А.Хәлим

**ТӨЕРЕМЛӘНҮ** *ф. диал.* Юанаю, тулылану. *Шактый төеремләнгән апасын олы юлга кадәр озатып куярга булды ул.* Туган як

**Төеремләнә башлау** Төеремләнү билгеләре күренү, сизелү. *Төеремләнә башлаган хатын*

**Төеремләнә төшү** Тагы да ныграк төеремләнү; бераз төеремләнү. *Кыз төеремләнә төшкән*

**Төеремләнеп бетү** Бик нык төеремләнү

**Төеремләнеп җитү** Тәмам төеремләнү. *Баярак, аны чакырырга кушкач та: «Берәр җылы сүз әйтер, бәлки», – дип уйлаган иде, хәзер исә Фирәзәнең нәфрәтле карашын, аннан да бигрәк тәмам төеремләнеп җиткән корсагын күргәч, Тынчурин күңелендәге өмет чаткылары капыл сүнде.* Г.Үзиле

**Төеремләнеп килү** Күзгә күренеп төеремләнү. *Кызның төеремләнеп килгән көмәненә күз төшереп, ана: – Балаңны харап итә күрмәсен каһәр суккан җан! – дип әрнеде.* Д.Каюмова

**Төеремләнеп тору** Төеремләнгән хәлдә булу, төеремләнгән булып күренү

**ТӨЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Төерләр булып оешу, төерләр барлыкка килү. *Аның чалбар балакларыннан төерләнеп каткан карларны куптарып төшерде.* М.Хуҗин

2) *күч.* Барлыкка килү, формалашу, оешу. *Күңелдә төерләнә башлаган тәшвишле уйларымнан чыга гына алмыйм бит.* Ф.Латыйфи

3) Чуалу, чияләнү. *Ахирәт дусларның телгә телләре чияләнеп, сүзләренә сүзләре бәйләнеп, уралып, төенләнеп һәм төерләнеп бетте.* Ф.Яхин

**Төерләнә башлау** Төерләнү билгеләре күренү, сизелү. *Бөреләр бүртә, төерләнә башлап, агачларның нәфисләнә, челтәрләнеп куера төшүеме?* Ш.Галиев

**Төерләнеп бетү** Тәмам төерләнү. *Атның тигәнәк белән төерләнеп беткән койрыгына карап бару туйдырган иде инде.* М.Хәсәнов.

**Төерләнеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыйгадан соң төерләнү; төерләнгән хәлгә килү. *Йөрәктә төерләнеп калган ул кичне бүгенгедәй хәтерли әле Гөлҗиһан.* Ф.Әмәк. *Бүгенге хәбәр Нуриянең тормышында бер могҗиза булды: күкрәгендә төерләнеп калган югалту хисе Насих күзләре белән карап торган оныгын – багалмасын күргәч, эреп юкка чыкты ---.* Р.Хәбибуллина

**Төерләнеп тору** Төерләнгән хәлдә булу. *Ул нәкъ элеккечә, балаларча беркатлылык белән, Зөфәр мине ярата бит, дип уйлады, шуңа эченнән генә куанды, һәм йөрәгендә күптән төерләнеп торган сызлавыгы бераз кими төшкән кебек булды...* Ә.Еники. *Төерләнеп торган күгелҗем яра белән капланган.* М.Хуҗин

**ТӨЕРЛЕ** *с.* 1) Төерләре булган, төерләрдән торган. *Пешергән коймагын, төерле дип, юынтык су чиләгенә илтеп аударды.* А.Гыйләҗев. *Җепләр тигез эрләнмәгән булса, тукыма тигез чыкмый, төерле була.* Г.Шакиров

2) *күч.* Дулкынланулы, борчулы. *– Рәмисә, зинһар, мине шашкан кешегә санама, – дип, төерле тавыш белән башлады ул.* Х.Камалов

3) *күч.* Тупас, усал, дорфа (тел, сүз тур.). *Юк, мондый ирнең булуыннан*

*булмавы артык. Туң йөрәкле, агач авызлы, төерле телле.* З.Мәхмүди

4) *күч.* Кимчелекле, бик үк җиренә җитмәгән, тиешлечә булып бетмәгән. *Әтнәлеләрнең беренче чыгышын төерле дип әйтмәс идем мин.* Ватаным Татарстан

**ТӨЕРЛЕЛЕК** *и.* Төерле булу. *Туфракның төерлелеге*

**ТӨЕРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Төере булмаган, тигез, бертөрле, бердәй составлы. *Аңа 100 г каймак кушабыз, төерсез генә масса барлыкка килергә тиеш.* И.Фәизов. *Бертөрле – төерсез, куе каймак кебек катнашма барлыкка килергә тиеш.* Сөембикә

2) *күч.* Яхшы, тиешле дәрәҗәдәге, кимчелексез. *Былтыргы бәйрәм «беренче коймаклар» булса да, төерсез, искитмәле булган иде.* Татарстан яшьләре

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Кимчелек, житешсезлек булмыйча; тиешле дәрәҗәдә. *Төзүчеләр һәм кредит оешмалары арасында эшне координацияләргә, күчеш мөмкин кадәр төерсез үтсен өчен, барлык механизмнарны җайга салырга кирәк.* Бөтендөнья татар конгрессы. *Иң мөһиме – рәссамның иҗат мөмкинлекләре булуын, беренче күргәзмәсе генә оештырылуга карамастан, аның дәрәҗәсендәге рәссам өчен төерсез килеп чыгуын билгеләп үтте ул.* Шәһри Казан

**ТӨЕРТАМЫР** *и. бот.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан туры сабаклы, алсу зәңгәр чәчәкле, бүлбе-тамырлары дарулар әзерләүдә кулланыла торган үлән үсемлек; күке яше; *русчасы:* **ятрышник**. *Үсемлекләр дөньясын 600 ләп төрдәге тамырчалы үсемлекләр тәшкил итә, аларның 89 ы – сирәк очрый һәм юкка чыгып бара торган төрләр (мәсәлән, шлемлы төертамыр (Orchis militaris), эре чәчәкле кәккүк читеге (марҗа башмагы дип тә әйтәләр).* Фәнни Татарстан. *Аларга пальма, камыш, күрән, орхидея, шулай ук безнең урманнарда сирәк очрый торган үсемлекләр – сәхләб (төертамыр), төнге миләүшә, башмакчәчәк керә.* Биология

**ТӨЕРТЕЛ** *и.* Тупас, дорфа сөйләшүче, усал телле кеше. *Гомерлек төертел*

**ТӨЕРЧЕК** *и.* 1) Кечкенә, вак төер. *Шул боз төерчекләре шома юлны скрипка кылы итеп сыза инде менә.* М.Хуҗин. *Лаванда орлыгы бик вак, шуңа күрә туфракта эре төерчекләр булырга тиеш түгел.* Туган як

2) *биол.* Берәр тере тукыма составындагы бүлбечек, тукымасының бер үсентесе. *Тәм тою органнары хезмәтен тәм төерчекләре үти.* Биология. *Ирекле азотны үзләштереп, аны органик кушылмаларга әверелдерә торган махсус бактерияләр – төерчек бактерияләре дә бар.* Химия

3) *махс.* Ювелир эшләнмәләрен бизәү, нәкышьләү өчен кулланыла торган, металл чыбыктан үрелгән бөтеркә. *Алкалары көмеш төерчекләр белән бизәлгән*

4) *күч. ирк.* Бик елгыр, җитез кечкенә бала турында. *Тик балага бер күз салу белән, аның ирennәре белән әнисенең имчәгенә тәрәлеп чәпелдәтеп имә башлавын күрүдән, бармаклары белән сабыйның алсу, җылы битенә орынудан бу төерчекнең үзенә никадәр якын, никадәр газиз икәнен бар җанытәне белән тойды.* Х.Мөдәррисова // Гомумән кечкенә җан иясе. *Әле юньләп каурый да чыкмаган алты чебеш, алты тере төерчек, барысы бер күч булып, бергә укмашканнар.* Г.Сабитов

**ТӨЕРЧЕКЛӘНҮ** *ф.* Төерчекләр хәленә килү, төерчеклегә әйләнү. *Эчетышы көйде егетнең, тамырларыннан шаулап аккан каны төерчекләнде, йөрәге тукталгандай булды.* Н.Гыйматдинова

**Төерчекләнә башлау** Төерчекләнү билгеләре күренү. – *Әле генә алган идек, инде төерчекләнә дә башлаган икән бу кофтаң, – диде әнисе, кәефсезләнеп.* Идел

**Төерчекләнеп бетү** Тәмам төерчекләнү, бик нык төерчекләнү. *Мамык төерчекләнеп беткән*

**Төерчекләнеп тору** Әледән-әле төерчекләнү; төерчекләнгән хәлдә булу. *Төерчекләнеп торган тукыма*

**ТӨЕРЧЕКЛӘҮ** *ф. махс.* Төерчек (*3 мәгъ.*) ясау, төерчек формасы бирү. *Ювелирлар, яка чылбыры ясаганда, төерчекләп нәкышьләү алымын еш кулланганнар.* Казан утлары

**ТӨЕРЧЕКЛЕ** *с.* 1) Төерчекләре (*1–2 мәгъ.*) булган. *Төерчекле тукыма. Төерчекле туфрак*

2) Бизәнү әйберләре ясаганда, металл чыбыктан үрелгән бөтеркәләр белән бизәлә торган (нәкышьләү ысулы тур.). *Беренче карашка авыррак сыман тоелган конструкция, асылташ балкышы һәм төерчекле нәкышьнең утәкүренмәле кебек тоелучан җиңеллеге белән, гүзәллек үрнәген тудыра.* Р.Шаһиева. *Казан музейларында металлны төерчекле нәкышьләү юлы белән эшләнгән бизәнү әйберләренең бай тупланмасы бар.* Казан утлары

**ТӨЗ** *с.* **1.** 1) Туры, кыегаймаган, бөгелмәгән; туры сызык формасындагы (күбесенчә вертикаль нәрсәләр тур.). *Ә наратлар шундый төз, шундый биек: башлары белән зәңгәр күкне терәп торткан кебек.* Л.Ихсанова. *Коңгырт куе чәчле, төз гәүдәле, тулган ай кебек түгәрәк битле, зур кара күзле Лилияне Мөхәммәт эшләгән мәктәпкә Ходай Тәгалә үзе җибәргәндер.* Т.Галиуллин

2) Бер юнәлештән чыкмаган, бөгелмәгән, тигез, туры сузылган. *Уйнап торган Көр атлардан, һич бозылмас Төз сафлардан Ташкын булып без агарбыз киң юллардан, Тау, чокырлар, урман, басу һәм кырлардан.* Т.Гыйззәт. *Гыйлемхан, тау башындагы кибетне сулда калдырып, үзенең беркатлы агач йортлары белән шәһәрдән битәр күбрәк авылны хәтерләткән озын, төз урамга борылды.* Ә.Сафиуллин

3) Тигез, шома, такыр, кытыршысыз, чокыр-чакырсыз (яссылык тур.). *Анда төз кыр икән, баш төртер түмгәк тә юк.* Х.Камалов. *Төшеңдә төз җирдә йөренгәнеңне күрсәң, иреккә чыгуың, бәлаләрдән котылуың дип юралыр.* Ф.Яхин

4) Тигез, яссы түбәле (лапас, әвеслек һ.б.ш. корылмалар тур.). – *Я, син нәрсә шамакай шикелле гурлаңны киереп торасың, авызыңа төкерим! – дип, Нургалинең юеш бугазыннан учлап тотты да төз лапаска таба этеп җибәрде.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Чын, дөрес, хак. – *Әгәр инде бу сүзләрдә хатам булса, олуг аганың ак күңеле мине кичерер; илченең аяк тайган җирләрен күрсәтер, төз юлга*

*барырга акыл бирер – безнең теләгебез шул, – дип тәмамлады.* Г.Ибраһимов. *Андыйларны төз юлга кертү – кәкре агачны төзәйтү белән бер, имеш.* Ф.Яхин

6) *күч.* Тәртипле, тәрбияле, инсафлы, туры. *– Ширпыңа да кул салганым юк, – диде Искәндәр, хәтәр төз кешедәй, хәтере калып.* Ә.Моталлапов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Туры сызык рәвешендә. *Аның да колхозчы булып, без кемнән ким дигәндәй, башын төз тотып, урамнардан үтәсе көннәре бар икән!* М.Хәсәнов. *Исмәгыйль абзый төз итеп коелган, зәңгәрсу төскә буялган өр-яңа коймаларына, кабаттан чыгып-чыгып, сөенечен яшерми карап торды.* Ф.Яхин

2) Кыегаймыйча, бөгелмичә, бөкрәймичә, кәкрәймичә. *Эченнән генә үзүзенә: – Буеңны да төз тот, башыңны күтәр, сынатма! – дип әмер биргәндәй итте.* М.Хәсәнов. *Ә инде сул якта – гәүдәсен төз тотарга тырышучы тәкәббер кыяфәтле бер ир.* Ф.Баттал

3) Төзәгән нәрсәгә туп-туры тидереп яки тидерерлек итеп (ату тур.). *Аның Актырнак исемле эте, төз атыр мылтыгы, йорт хайваннары, кош-кортлары да бар икән.* А.Алиш. *Үсмерләр һәм яшьләр арасында махсус мишеньгә ату ярышлары оештырылган һәм иң төз атучыларга бүләк бирелгән!* Р.Әхмәтьянов

4) Гадел рәвештә, намус белән, намуслы булып. *Һәм ышандым: иманың нык булса, төз калырга дәрман җитә ул!* Р.Фәйзуллин

◊ **Төзгә кату** Бик тураеп, киерелеп басу, төз күренергә тырышу. *Телеграф баганасы кебек төзгә каткан, какча гәүдәле урта яшьләрдәге кеше ул.* М.Әмирханов. *Мәҗбүриләп чыгарган кебек төзгә катып басып тору да читтән матур күренми.* Туганайлар. **Төз җирне түмгәк итү** *к.* **тигез җирне түмгәк итү**. *Алар, сарык көтүе төсле, ләм-мим димичә, кем өчендер шунда барып, төз җирне түмгәк итәләр.* Г.Рәхим

**ТӨЗӘГЕЧ** *и.* Ату коралларында төзәү җайланмасы; *русчасы:* **прицел**. *Хәзер ул аны мылтык төзәгечендә ала да... ыргакка басарга тели, ләкин бармагы бөгелми.* Н.Хәсәнов. *Димәк, мушка, төзәгеч һәм чакма белән мавыгып, ул карабинның тимер кадакланган авыр түтәсе барын исеннән чыгарган икән.* Р.Кәрами

**ТӨЗӘЙТКЕЧ** *и. махс.* Нәрсәне дә булса төзәйтү өчен кулланыла торган махсус җайланма. *Иң яхшысы – универсаль төзәйткечләр, аларның тактачыклары җәелмәле, араларындагы ярыкны үзгәртеп була.* Яшь натуралистларга. *Бөҗәкләр куелган төзәйткечне коры, ләкин эссе булмаган, тузан һәм артык яктылык кермәстәй урында тотарлар.* Бөҗәкләрне энәгә кадау серләре

**ТӨЗӘЙТҮ** *ф.* Төз (*1–2 мәгъ.*) хәлгә китерү; турайту. *Рәйсә кулларын абыйсының муеныннан алды, Галияр сыгылыбрак гәүдәсен төзәйтте, оныгының мондый хәрәкәтенә Сәрвия иртән игътибар итеп җиткермәгән иде, хәзер исә, Галиярның гәүдәсен үз җаена тотарга тырышуының сәбәбе бар икән дип, күңеленә салып куйды.* М.Хуҗин. *Аңа кәкре кадакларны төзәйтергә куштылар.* А.Тимергалин

**Төзәйтә башлау** Төзәйтергә тотыну. *Тимерчыбыкны төзәйтә башласалар да буладыр.* Р.Вәлиева

**Төзәйтеп алу** Тиз генә төзәйтү. *– Менә бу кадакларны гына төзәйтеп алам да эшкә керешәм, – диде әтисе.* Казан утлары

**Төзәйтеп кую** Тиз арада яки алдан төзәйтү. *Кәкре кадакларны төзәйтеп куйдылар*

**Төзәйтеп тору** Даими яки әледәнәле төзәйтү; әле, сөйләү моментында төзәйтү. *Кыекларны вакытында төзәйтеп тормасаң, бетте баш.* Мәйдан

**ТӨЗӘЛМӘС** *с.* 1) Бөтенләй төзәлми, элекке сау хәленә кайтмый торган. *Әнә минекенең кыяфәтенә генә күз сал: өске ирене өстендә төзәлмәс җөй, борыны ямьшәйгән, уң колагы ертык, алгы тешләре коелган...* Ф.Имамов

2) Төзәтеп булмаслык, үзгәртеп, яхшыртып, кире кайтарып булмаслык (эш-гамәл һ.б. тур.). *Ләкин, төзәлмәс хата ясамас өчен, бәхәскә кушылмады, тешен кысып түзде: кемнең дә булса бу кешегә дөрес җавап бирүен көтте.* Г.Әпсәләмов. *--- икенчедән, әле кайчан гына ахирәт дуслардай гәпләшкән, кай мәлне хәтта яшерен серләрен уртаклашкан Шәмсүнгә карата төзәлмәс хыянәт ясавы шомлы юшкын сыман күңеленә утырды.* А.Вергазов

3) Төзәтеп, үзгәртеп, яхшыртып булмый торган (начар гадәт, холык һ.б.ш. тур.). *Без аның төзәлмәс алкаш икәнен белмәдек.* Х.Камалов. *Бу азан Җиһан әбидә, сабый балаларда, төзәлмәс хулиганнарда – бар авыл халкында да иман нуры кабызды.* А.Шәйхин

4) Үз карашларын, фикерен һ.б. үзгәртми торган. *Мин – мәңге төзәлмәс милләтче юләрдер ---.* И.Биектаулы. *«Капитан күперчегендә» торучы Мәскәү сәясәтчеләре – төзәлмәс оптимистлар, әлбәттә.* Н.Шәрифуллин

5) Үтми, онытылмый, бетәшми торган (рухи газап һ.б.ш. тур.). *Шул ук вакытта аның килүе бу гаиләдә төзәлмәс яраның авыртуын кузгата иде булса кирәк.* А.Гыйләҗев

**ТӨЗӘЛМӘСЛЕК** *с. к.* **төзәлмәс**. *Әлеге яман хәбәрләр ишетелгәч, гомер буе кан саркып торырлык мәңге төзәлмәслек җәрәхәт алган сыман булды мәрхүмә.* М.Хәсәнов. *Алар алдында гына түгел, һәрбер авылдашы алдында, һәрбер танышы алдында үзен төзәлмәслек җинаять эшләгән кеше кебек итеп тойды.* Н.Фәттах

**ТӨЗӘЛҮ** I *ф.* 1) Яра, җәрәхәт бетәшү; сызлау, авырту басылу. *Шулай булмый ни: чираттагы яралары төзәлгәч тә, вакытыннан алда туган авылына ялга кайтып килеше ич аның.* Р.Низамиев. *Синең яраң әллә ни авыр түгел: син – аяклы яралы, аннары туган җирең дә якын гына, кулың төзәлгәнче, өеңдә дәвалана тор, ә бездә авыр яралыларга да урын җитми, дип кайтарып җибәргәннәр.* В.Нуруллин

2) Сәламәтләнү, савыгу, саулык яңадан кайту. *Ләкин доктор аңарга: – Төзәлергә телисеңме? – диде.* Һ.Такташ. *Төзәлгән яралыларны озаткан көнне, ярты төн урталарында, госпиталь хуторына немец «мессер»лары бомба ташлап киттеләр.* Х.Камалов

3) Җайлану, рәтләнү, яхшыру (эш-хәл, мөнәсәбәт һ.б.ш.). *Аның чират мәсьәләсендәге бер китек ягы да төзәлгән кебек булды.* Һ.Такташ

4) Әйбәтләнү, яхшы якка үзгәрү (һава торышы тур.). *Ягъни җил кояш чыгышы тарафыннан килсә, һава байтак көннәргә чаклы төзәлеп торыр.* К.Насыйри. *Кояш ачылыр, һава төзәлер, рәхмәт яңгыры явар, шуның соңында без дә көткәнебезне күрербез.* Г.Ибраһимов

5) Төзек хәлгә килү; төзәтелү, ремонтлану. *Җимерек урыннарның төзәлгәнен Күрсә, аның күңеле хушлана.* М.Гафури. *Кызлар ике чәйнек бушатканда, үтүк төзәлгән иде инде.* К.Кәримов

6) *күч.* Яхшыру, күтәрелү, әйбәтләнү (кәеф, күңел халәте тур.). *Бу да бераз вакыттан өенә кайтса, хатынның кәефе төзәлгән булса кирәк ки, өендә булмыйча, башка берәүнең торагында булган.* Г.Баруди. *Шул көннәрдә әтинең кәефе бераз төзәлгән дә кебек булып китә.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Бетү, кимү, борчымый башлау, онытылу (әрнү, борчу һ.б.ш. тур.). *Югалту яралары әкренләп төзәлсә дә, сагыш китми, сагынып искә ала торган вакыйгалар, әңгәмәләр хәтердә еш кабатлана.* Т.Миңнуллин // Тынычлану, борчулардан арыну. *Баягы әрнүле уйлардан соң аның күңеле төзәлмәгән иде әле.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Кимчелек, җитешсезлек, начар гадәт һ.б.ш.лардан арыну. *Минем уемча, без бу дәфтәргә семья эчендә булган барлык кимчелекләрне яза барырга, шуны укып төзәлергә тырышырга тиеш идек.* Г.Кутуй. *Төзәлмәгәч төзәлми инде бу Сидоров.* С.Шәрипов

**Төзәлә бару** Торган саен төзәлү. *Янында утырган, үзенә көннән-көн ошый барган Сәеткә Әнисәнең үзе турында сөйлисе, хәтта ярасы бик тиз төзәлә барган җилкәсенә ятып, шыңшып-шыңшып елыйсы килә.* Т.Галиуллин. *Әкренләп йөрәк яралары да төзәлә барды.* Р.Вәлиев

**Төзәлә башлау** Төзәлү билгеләре күренү. *Гүя аның эшләре төзәлә башлаган да кебек, киләчәк көне өмитле дә кебек иде.* Г.Ибраһимов. *Кулбаш ярасы төзәлә башлаган шикелле булса, аяктагы кечкенә ярада бозылу билгеләре күчәя.* Х.Камалов

**Төзәлә төшү** Бераз төзәлү, тагын да төзәлү. *Ярагыз төзәлә төште.* Т.Гыйззәт. *Командир, ярасы төзәлә төшкәч, уйлана: без комиссар белән дөрес эшләгәнбез.* Х.Камалов

**Төзәлеп бетү** Тәмам төзәлү, тулысынча төзәлү. *Тик менә тәнендәге җәрәхәте генә төзәлеп бетмәгән.* Н.Әхмәдиев. *Тән яралары да, күңел җәрәхәтләре дә төзәлеп бетмәгән, әле дә әрнеп торган кешеләр күпме!* Т.Нәҗмиев

**Төзәлеп җитү** *к.* **төзәлеп бетү**. *Чирек гасыр буе төзәлеп җитмичә, әле һаман да еш-еш кына ачылып, карт укытучының теңкәсенә тия торган авыр яра нинди фаҗигага китермәс!* Г.Сабитов. *Куянның аягы төзәлеп җитте.* Р.Батулла

**Төзәлеп килү** Төзәлүгә таба бару, әкренләп төзәлү. *Яңактагы яра яңа төзәлеп килә.* Ф.Яруллин. *Аның әйтүенә караганда, Җәлилнең иңбаш сөяге чәрдәкләнгән, сул кулы асып бәйләп куелган, ә күкрәгендә инде төзәлеп килә торган пуля ярасы булган.* Р.Мостафин

**Төзәлеп киту** Берәр нәрсә тәэсирендә төзәлү. *Берәүләр: «Без укучыларны артык каты режимда тотабыз бугай, болай ук кирәкмәс иде, Гомәр бит хәзер бөтенләй төзәлеп китте, Фәлинәнең укуы начар якка үзгәрмәде», – диделәр.* Г.Рәхим. *Торсаң, бик каты итеп чәй ясыйм, шундук башың төзәлеп китәр.* Ә.Сафиуллин

**ТӨЗӘЛҮ** II *ф. төш. юн. к.* **төзәү**. *Ул шунда ук, үзенә төзәлгән автомат һәм мылтык көпшәләрен күреп, чәчрәп урыннан торды.* А.Расих. *Әллә үзен үзе белештерми җиргә тәгәрәве булышты, әллә авыр яралы Нәзирнең хәлсезлеге, ашыгуы ярдәм итте: Байкучатовның күкрәгенә төзәлгән пулялар аның беләген һәм иңбашын гына чагып узды.* Т.Әйди

**ТӨЗӘНҮ** *ф. сир. к.* **төзәтенү** (*1 мәгъ.*). *Төзәнгәч, ясангач, сеңлесе Җәбиргә башка вакыттагыга караганда чибәррәк булып күренде.* Н.Фәттах. *Анда барыр алдыннан озаклап бизәнде, төзәнде.* Н.Көбәш

**ТӨЗӘНҮ́-БИЗӘНҮ** *ф.* Озаклап, җиренә җиткереп бизәнү; чәчне, битне, өс киемен тәртипкә китерү. --- *иртә-кич әле бер нәрсәсен, әле икенче нәрсәсен алыштырып кия иде, һәм шунлыктан ул кайберәүләргә бертуктаусыз төзәнергә-бизәнергә яратучан купшы кыз булып, хәтта аксөяк, иркә кыз булып күренә иде.* Н.Фәттах. *Матур киемнәр дә киендереп тормый, төзәнергә-бизәнергә дә кушмый.* Р.Миңнуллин

**ТӨЗӘНҮ́-ЯСАНУ** *ф.* Тышкы кыяфәтне (киемне, йөзне, чәчне) матур, пөхтә, купшы итү. *Аның матур киенеп кайтып, төзәнеп-ясанып йөрүеннән көнләшүдән киләдерме ул.* Р.Миңнуллин. --- *Гүзәлия кибетләргә сугылды, чәчтарашханәгә кереп, төзәнеп-ясанып чыкты.* М.Әмирханов

**ТӨЗӘТЕНҮ** *ф.* 1) Үзенең тышкы кыяфәтен – өс киемен, битләрен, чәчләрен тәртипкә китерү; бизәнү-ясану. *Рәмзияниләр уйлый торгандыр, көзге каршысына басып төзәтенергә кереште.* Н.Әхмәдиев. *Тегесе аны тыңлап төзәтенә, кара яулыгын күзенә төшереп бәйли башлады.* А.Хәлим

2) *диал.* Йорт-җиргә ремонт ясау, тагын да яхшырту, матурайту. *Башланды чистарыну, төзәтенү, мичләр, морҗалар, мунча мичләре агарту, чаршау, чыбылдык, күлмәкләр тегү, китте тазарыну-юыну, киенү-ясану.* Г.Бәширов

**Төзәтенә башлау** Төзәтенергә тотыну. *Шуркай хатынга ишарә ясады, хатын үз урынына барып утырды да төзәтенә башлады.* Р.Батулла. *Гөлчәчәк фырт кына урыныннан сикереп торды, көзге каршына басып ясана, төзәтенә башлады.* Х.Ибраһим

**Төзәтенеп алу** Бераз гына, тиз арада төзәтенү. *Кырынып, төзәтенеп алганнан соң: – Уятмасаң, бу балдыз тора белмәс, – дип, сәндерәгә менеп китте.* Ф.Яруллин. *Кыз тиз-тиз генә төзәтенеп алды, күз яшьләрен сөртте.* Д.Бүләков

**Төзәтенеп җибәрү** Бер мәртәбә, билгеле бер моментта, тиз генә төзәтенү

**Төзәтенеп йөрү** Һәрвакыт төзәтенгән булу. *Сара апа, бизәнеп, төзәтенеп йөргәнгәме, бер дә карт, өлкән кешегә охшамый иде.* Сөембикә

**Төзәтенеп кую** Тиз генә төзәтенү; алдан төзәтенү. *Хатын, акланырга теләгәндәй итеп, төзәтенеп куйды.* М.Хәсәнов

**Төзәтенеп тору** Хәзерге моментта төзәтенү; гел, һәрвакыт, әледән-әле төзәтенү. *Рәмзия ишеген ачып кергән дә көзге каршында төзәтенеп тора.* Н.Әхмәдиев. *Төзәтенеп торган кызны күрмәмешкә салышты ул.* М.Хәсәнов

**ТӨЗӘТМӘ** *и.* 1) Әйтелгән яки язылганнан соң ачыкланган берәр хатаны төзәтә, дөресли торган үзгәреш, өстәмә; төзәтеп әйтү яки язу. *Анысын да без төзәтмә итеп законга кертсәк яхшы булыр иде.* Т.Миңнуллин. *Бу безнең тарафтан чыккан үзгәреш түгел, ә дин әһелләре мөрәҗәгате белән эшләнгән төзәтмә булды.* Н.Алан

2) Үзгәртмә, ачыклама, өстәмә. – *Бөке кебегрәк итеп, – дип, аның сүзенә төзәтмә кертте Мәмәт ага.* А.Тимергалин

**ТӨЗӘТТЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **төзәтү**. *Манараны һәм асма күпер белән капкаларны әмир Хаҗи яңадан төзәттерә, каладан оста Дәүранны китертеп, ел буена шунда эшләтә.* М.Хәбибуллин. *Ул кызлардан, талап, өй эшләрен күчерә, иншаларындагы хаталарын төзәттерә иде.* Н.Гыйматдинова

**Төзәттерә башлау** Төзәттерергә тотыну. *--- яшь киленнәр Салагыш базарыннан бизәкле тырмалар, ак яулыклар кайтарта, алъяпкычларына тамбур җебе белән болын чәчәкләре чигә, гармунчы егетләр көмеш телле тальяннарын осталардан төзәттерә башладылар...* Г.Ахунов

**Төзәттереп алу** Бераз төзәттерү; тиз генә төзәттерү. *Машинасының сул як крылосында бераз яньчелгән урын бар иде, аны бер якын танышыннан төзәттереп алды.* Ф.Яруллин

**Төзәттереп бетерү** Төзәттерүне төгәлләү. *Төп бурыч – кыска вакыт эчендә урып җыю техникасын төзәттереп бетерү.* Ватаным Татарстан

**Төзәттереп карау** Сынау максаты белән төзәттерү. *Кемнәргә генә биреп төзәттереп карамады Инзирә, барыбер йөреп китмәде.* Г.Галиева

**Төзәттереп тору** Әледән-әле, һәрвакыт яки хәзерге моментта төзәттерү. *Күперне һәрдаим карап, төзәттереп торганнар.* З.Дәүләтшин

**ТӨЗӘТҮ** I *ф.* 1) Төзек хәлгә китерү, файдаланырга яраклы итү, ремонтлау. *Өй-абзар түбәләрен дә төзәтте әнә: Мостафа үзе балта остасы булса да, бер аяксыз килеш анда менә алмый, ә сугыш башланганнан бирле кул тимәгән түбәләргә карау-суккалау кирәк иде.* М.Хуҗин. *Халык тәрәзә рамнары ясау, урман кисү, сәгать төзәтү белән шөгыльләнә.* Х.Садри

2) Төз итү. *Сез генә, аталы-уллы, дөньяның кәкресен төзәтерсез бик!* Х.Камалов. *Анадан бөкре туганны кабер генә төзәтер, ди торган идең үзең.* Т.Галиуллин

3) Дәвалау, савыктыру, сәламәт хәлгә китерү. *Бүреләр үз ярасын үзләре ялап төзәтә.* Ф.Яруллин. *Эш йөрәктәге яраларны тизрәк төзәтер, сагынуларны да киметер кебек тоела.* Ф.Тарханова

4) Өс-башны, чәчне, тышкы кыяфәтне тәртипкә китерү, рәтләү. *Күзенә таба төшеп үскән кашларын уңаена сыпырды, төзәтте.* А.Алиш. *Нәкыя җиңгәсе чакырып дәшкәч, Рәхилә сискәнеп торып басты, күлмәгенең киң итәкләрен таратып җибәрде, чәчен төзәтте, күз төпләренә куна башлаган җыерчыкларга кагылып, сыпырып алырга теләгәндәй, сыйпап-сөеп куйды...* Г.Гыйльманов

5) Хаталары, җитешсез яклары булган нәрсәгә үзгәрешләр кертү; үзгәртү. *Ул хатларымдагы хаталарны кызыл кара белән төзәтеп, мине рус телендә дөрес язарга өйрәтә иде.* Ф.Яруллин

6) Эш-гамәлдәге ялгышларны, хаталарны, кимчелекләрне бетерү. *Аның өчен бигрәк тә гомеренең файдасызга үтүен, ләкин хәзер бу хәлне төзәтү мөмкин түгеллеген тануы авыр.* Г.Ибраһимов. *Ялгышканыңны аңлап, барысын да вакытында төзәтерсең дип уйладык.* Р.Вәлиев

7) Кемнең дә булса сүзләрендәге, холык-фигылендәге һ.б. хаталарына күрсәтү. *Бәлки, мин ялгышамдыр, ялгышсам, иптәшләр төзәтерләр.* М.Мәһдиев. – *Кайнаттык, диген! – дип көлеп төзәтте аны Әлифә. – Кайнатма бит ул!* М.Маликова

8) Кемне дә булса җитешсез, кимчелекле, начар гадәтләреннән, бозыклыгыннан арындыру, рухи яктан яхшырту. *--- хатыннарның хәлен яхшырту, аларны тәрбияләү, холыкларын төзәтү вә гакылларын үткенләү өчен, өстебезгә гакыл белән шәригать кирәк тапкан эшләрнең берәрсен эшләгәнебез бармы?* Г.Буби. *Әкият баланың рухи дөньясын баета, фантазиясен үстерә, холкын төзәтергә һәм тормышка карашын ачыкларга ярдәм итә.* Л.Җамалетдинов

9) Җәмгыять өчен зарарлы, бозык, җинаятьчел, яман гадәтләрдән арындыру, тәрбияләү. *Ике малайның олысы төзәтү лагереннан алдарак кайтты.* М.Мәһдиев. *Ул узган гасырның 90 нчы еллар азагында, Түбән Камадагы 4 нче төзәтү колониясендә берничә ел лаеш шулпасы чөмерә.* Н.Вахитов

10) Түбән билгедән соң уңай билге алу. *Бер тапкыр үзе урамда йөргән, ә үзе: «Мин мәктәптә билгеләр төзәтәм әле», – дип, өйдәгеләр колагына токмач элгән.* Л.Закиров. *Ул, үзенә бишле куюларын сорап, университет укытучыларына мөрәҗәгать итеп аргач, хәтта Мәскәүдәге ректорга кадәр барып җиткән, ләкин аңа билгене төзәтергә рөхсәт итмәгәннәр.* Безнең гәҗит

11) *күч.* Берәр эш-хәлне, мөнәсәбәтне җайга, рәткә салу, җайлау; көйләп җибәрү. *Чыннан да ферманың эшен төзәтү өчен йөриләрме икән әллә булмаса.* Т.Гыйззәт

**Төзәтә бару** Акрынлап, аз-азлап төзәтү; булган берсен эзлекле рәвештә төзәтү. *Тәнкыйть яратмыйсың икән, дия күрмәгез, мин тәнкыйть белән үстем, хаклы рәвештә ясалган файдалы тәнкыйтьләргә колак салып, әсәрләремне һаман төзәтә барам, һәрберсен кабат-кабат яңадан язам.* Т.Гыйззәт. *Үз балаңа да барын да әйтеп, төзәтә барып булмый.* Ш.Галиев

**Төзәтә башлау** Төзәтергә тотыну. *Дүрт ел буена җилкәләребездә күтәреп килгән авыр сугыш йөкләрен бу көннән селкеп ташлыйбыз да, башларыбызны югары күтәреп, шул сугыш нәтиҗәсендә туган яраларыбызны төзәтә башлыйбыз.* Т.Гыйззәт. *Балачактан гармунчы булып үскән егет тиздән гармуннар көйли, төзәтә башлый.* Г.Мөхәммәтшин

**Төзәтә килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә тәзәтү. *Мин ваклана башласам, Равил Габдрахманыбич гел мине төзә-*

*тә килә ---.* Р.Батулла. *Пәйгамбәребез исән чакта, әлбәттә, ялгыш аңларга урын калдырмаган, төзәтә килгән, үзеннән чыгып аңлатучыларны тыйган.* Мәдәни җомга

**Төзәтә тору** Һәрвакыт, әледән-әле төзәтү. *Дөньяны төзәтә торгач, бөтен дөньясы белән бозылышып беттек!* Ш.Галиев. *Апасы гел өйрәтә, Хаталарын төзәтә. Төзәтә торгач туя, «Начар» дип язып куя.* Р.Вәлиева

**Төзәтеп алу** Тиз генә төзәтү. *– Булыр, булыр, – Сабир бабай бүреген төзәтеп алды.* Г.Әпсәләмов. *Сумкага үрелгән җирдән тукталып калдым да, дәртле-бәхетле хәрәкәтләр белән, автобустан чыккан өс-башымны, чәчләремне төзәтеп алдым.* М.Кәбиров

**Төзәтеп бетерү** Барысын да төзәтү; тәмам, ахырга кадәр төзәтү. *Хәер, чыгыш ясаучы, интервью бирүче кешенең сөйләмен тикшереп, төзәтеп бетерү мөмкин түгел.* Р.Юсупов. *Бервакыт сөйләшеп утырганда, Ләйләнең әтисе: «Сез, балалар, безне гафу итегез инде, дөньяны төзәтеп бетереп булмады», – диде.* М.Маликова

**Төзәтеп бирү** Кем өчендер төзәтелү. *Элегрәк ялгыз карчыкларга, тол хатыннарга пыяла кисү, тәрәзә рамнарын төзәтеп бирү кебек хезмәтләрне гел бушлай эшләде Харрас.* Г.Галиев. *Ул арада тынгысыз Әмирҗан, сорап-нитеп тә тормыйча, искереп, каерылып төшкән бернигә ишекне рәтләп куйды, әллә күпме өстәл-урындыкны төзәтеп бирде.* Г.Гыйльманов

**Төзәтеп җибәрү** Бераз, берникадәр төзәтү. *Булмышыннан фикере ашып китә икән, ашыкмыйча, иплә генә төзәтеп җибәрергә дә була.* Г.Хөсәенов. *Яше 80 нән өстен булуга карамастан, өлкән шагыйребезнең хәтере әйбәт: күпчелек шигырьләрен күңелдән белә, ялгышсаң-нитсәң төзәтеп җибәрә ала икән.* Ф.Яруллин

**Төзәтеп кую** Тиз генә төзәтү. *Елыймелыйм дип мәлҗерәп торган улының бүреген төзәтеп куйды.* К.Тинчурин. *Тузган йорты алдындагы сынык рәшәткәләрне төзәтеп куйды, җепсә баганаларының ныклыгын тикшерде.* Н.Хәсәнов

**Төзәтеп чыгу** Һәрберсен берәмберәм төзәтү, барысын да төзәтү. *Һәр мәкаләне үзе укып, үзе төзәтеп чыкты.* Р.Миңнуллин. *Чыннан да, мин өч көн рәттән, дәрестән соң калып, барысын да төзәтеп чыктым.* Р.Сәгъди

**ТӨЗӘТҮ** II *и.* Җитешсез якларны, хата-кимчелекләрне бетерү максаты белән кертелгән төзәтмә, үзгәреш. *Ул төзәтүләр, үзгәртүләр, гадәттә, секциядә яки театрда укыганнан соң була, ләкин әсәрнең берничнди дә төзәтүләргә мохтаҗ булмаганы яхшырак түгелмени?* Н.Нәҗми. *Вёрстка, корректура, төзәтүләр – барысы да Мәрьямнең үз өстендә.* С.Ибраһимова

**ТӨЗӘ́Ү** *ф.* 1) Мылтык, туп һ.б.ш. коралларны җанлы-җансыз нәрсәләргә яки кешеләргә турылау, төбәү. *Назимов ыңгырашып җибәргәч, бер адым артка чигенеп, автоматын төзәде.* Г.Әпсәләмов. *Ә Илнур моны бөтенләй көтмәгән иде, мылтыгын аларга төзәгән килеш, шаккатып карап торды.* Ф.Яруллин

2) *сир. к.* **төбәү** (*2 мәгъ.*). *Әминә кинәт кенә күзләрен Хәятка төзәде.* Ф.Әмирхан. *Бу хурлыкка ковбой Жора түзмәде, Чепелт күзен көпшә итеп төзәде: «Тәсбихеңнең тарт та соңгы төймәсен Укый башла әҗәлеңнең сүрәсен!..»* Р.Идиятуллин

**Төзәп бетерү** Төзәлгән хәлгә китереп әзерләү. *Зарипов, төзәп бетергәч, алга таба биноклен төбәде, кулын изәп кенә рычагны тартырга кушты.* Х.Камалов

**Төзәп карау** Төзәргә тырышу; сынау өчен төзәү. *Мин бары тик төзәп кенә карадым.* Р.Батулла. *Үзем чамалаганча төзәп карыйм тегене [мылтыкны].* М.Маликова

**Төзәп кую** Тиз арада төзәлгән хәлгә китерү. *Иң элек бәләкәй Чиж, чокырга шуышып, автоматын әлеге йортның ишегенә төзәп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Нәҗип тупны яңадан корды да күперчеккә төзәп куйды һәм, башнядан яртылаш чыгып, карый, тыңлый башлады.* И.Хуҗин

**Төзәп тору** Озак вакыт дәвамында төзәү; әле, хәзер төзәү. *Бу күренешне карап торган Хәбиров, кыҗрап, нидидер рәхәтлек белән автоматын шул немецларга төзәп торды һәм, ышанычлырак булсын өчен, күкрәгән тутырып сулыш алды да тәтесенә басты.* Х.Камалов

**Төзи башлау** Төзәргә керешү. *Шул ук вакытта җиңел тупларын күтәреп килгән артиллеристлар да тупларын дошман амбразурасына төзи башладылар.* Г.Әпсәләмов. *– Күрерсез, бер атуда мин боларның яртысын кырам, – дип, аларга мылтыгын төзи башлый.* А.Хәсәнов

**ТӨЗӘҮЧЕ** *и. хәрби* Туп көпшәсен тиешле урынга атып тидерерлек итеп төзәгечкә карап боручы солдат; наводчик. *Төзәүче элегрәк яраланган иде. Степанов орудиедан берүзе ата.* Г.Әпсәләмов. *Чөнки төзәүче, коручы, мина ташучы бер-берсенә якын тора икән, ату рәтле килеп чыкмый.* С.Поварисов

**ТӨЗӘЮ** *ф.* Төз (*1, 2 мәгъ.*) хәлгә килү. *Какча гәүдәле, хәрәкәтчән бабай тагын да төзәеп, дәртләнеп китә ---.* А.Алиш. *Җилкәләре салынкы ук түгел үзенең, ит кунса, киңәеп төзәерләр.* М.Хуҗин

**Төзәеп китү** Билгеле бер моменттан төзәю. *Тазарып, матурланып, гәүдәләре төзәеп киткән.* Туганайлар

**Төзәя башлау** Төзәю билгеләре күренү, сизелү. *– Төзәя башлады, – диде сыңар күз һәм, ата каздай, муенын сузып куйды.* Х.Сарьян

**ТӨЗЕК** *с.* **1.** 1) Бозылмаган, файдаланырга ярый торган; ватык, бозык урыннары булмаган. *Якын-тирәдә генә төзек телефон да табылмады.* Р.Рахман. *Мөмкинлек булганда: юллар төзек булып, автобуслар исән-имин йөреп торса, ата-аналар каршы килмәсә, балаларны күрше зуррак авылдагы мәктәпкә йөртеп укытырга да була.* С.Әхмәтҗанова // Сәламәт, зарарланмаган. *Бер кулы төзек кеше әллә ниләр майтара ул...* Г.Әдһәм

2) Тәртиптә торган; җимерелмәгән, ямьсезләнмәгән. *Элек Гөлшәһидә ничектер күреп бетерми идеме, больница аңа ярыйсы төзек булып тоела торган иде.* Г.Әпсәләмов. *Бүген Актанышка сокланып туя алмыйсың: урамнар төзек, капка-коймалар буялган,*

*тротуарлар чиста, мул яшеллек...* И.Фәйзрахманов

3) Билгеле кагыйдәләргә туры килә торган, дөрес, төгәл. *Саф татарча төзек, дөрес җөмләләр белән Нәркис сөйләде.* М.Мәһдиев. *Үз әсәрен төзек сюжетка кормаган авторлар бер вакыйгадан икенче вакыйгага кинәт сикереш ясыйлар.* Ф.Яруллин

4) *мат.* Барлык яклары һәм барлык почмаклары үзара тигез булган. *Төзек дүртпочмак булып саф-саф тезелгән күчмә шәһәрчектә шылт иткән тавыш юк, вагоннарга кереп-чыгып йөрүче дә күренми, хәтта участок конторкасы ишегенә дә йозак эленгән иде.* Ж.Рәхимов

5) *к.* **төз** (*1–2 мәгъ.*). *Риза абый төзек ап-ак тешләрен балкытып елмайды гына.* Т.Миңнуллин. *Акчасын китереп бирергә ашыкмаган иде, ике көннән теге төзек ханым өенә килеп җиткән, өстәмә лекция укып күндерде.* К.Кәримов

6) Җайланган, көйләнгән, рәткә салынган, тәртипле. *Тормышлары төзек, тату, мәхәббәтле гаилә.* Г.Гомәр

7) *күч.* Таза, мул тормышлы, бар нәрсәсе дә җитеш. *Һәркөн авызын, мыегын майлап, халык арасына чыгып, мактанып: «Әлхәмделиллаһ, өс-баш ул кадәр төзек булмаса да, ашау-эчүемез яхшы: һәркөн кәбаб та мәбаб, тавык ите».* К.Насыйри. *Яңа, төзек тормыш корырбыз, дип, Вәгъдәләрен алдың, караттың.* М.Җәлил

8) *күч.* Каршылыклар, аңлашылмаучылыклар булмаган, тату (үзара мөнәсәбәт тур.). *Менә килен, арабыз төзек түгел, ди.* Т.Гыйззәт

9) *күч.* Билгеле бер тәртиптә, катгый, төгәл. *Һәммә кеше дә тоташ: «Һа-һу-һи-һа-һа, һиһа-һаһа», – шикелле ишетелгән бик нык гөрелте ясап, барлык көчне төзек «такт»ка салып бара.* Ш.Камал

10) *күч. иск.* Начар, бозык уй-фикерләре булмаган, саф. *Күңелебез төзек түгелмени? Тәңреләр каршында син язык кыласың, ягы йоланы өстен күреп мактыйсың.* А.Гадел // Әйбәт, күтәренке. *Дуслар янына инде ул шактый төзек кәеф белән кайтып керде.* Ә.Баян

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бозылмаган хәлдә, файдаланугa әзер. *Моның өчен техникадан югары җитештерүчән файдалану, машиналарның һәрвакыт төзек булуы кирәк.* Т.Нәҗмиев

2) Төз булып, туры итеп. *Хәлфә ялт итеп чатыр эченә керә дә Чикерткәгә: «Тагын бер төркем килгәннәр, төзек кенә утыр, хәзер кертә башлыйм».* Ә.Еники

3) Әйбәт, җайлы, тиешле тәртибе белән. *Концерт алтынчы пунктына кадәр әйбәт, төзек барды.* М.Мәһдиев. *Аларның һәрберсен төзек эшләтү, запас частьлар табып аякка бастыру гаять авыр проблемага әверелә иде.* Т.Нәҗмиев

**ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ** *ф.* Төзек хәлгә китерү, төзәтү, рәтләү. *Инде урамыбызда юлны төзекләндерделәр.* З.Хәким. *Әйдә эшләсеннәр, баесыннар, зур уңышларга ирешсеннәр, җирләрен эшкәртсеннәр, шәһәр һәм авылларын төзекләндерсеннәр.* И.Хуҗин

**Төзекләндерә бару** Эзлекле рәвештә рәттән төзекләндерү. *Йорт тирәсен елдан-ел төзекләндерә баралар*

**Төзекләндерә башлау** Төзекләндерергә керешү. *Россия белән үзара налог мәсьәләләре хәл ителеп бетмәсә дә, үзебезнең позициядә тору нәтиҗәсендә, бераз шәһәрләрне төзекләндерә башладык, авыл җирләренә ярдәмне арттырдык.* Р.Миңнуллин. *2011 елның 15 августыннан без Морты авылында урнашкан конторaны төзекләндерә башладык.* Д.Вәлиев

**Төзекләндерә төшү** Бераз төзекләндерү. *Мәктәп бинасын төзекләндерә төштек*

**Төзекләндереп алу** Тиз арада төзекләндерү. *Шуны булдырмый калу өчен, нык бәдәнле егетләр Сөембикә манарасына аркан бәйләп, манараны кире якка тартып торырга тиешләр, ул арада таш салучылар манараның нигезен бераз ныгытып, төзекләндереп алырга тиеш булачаклар.* Безнең гәҗит

**Төзекләндереп бару** Эзлекле рәвештә, әкренләп төзекләндерү. *Әлегә биналарны төзекләндереп баралар, соңрак буяу эшләренә тотыначаклар.* Шәһри Казан

**Төзекләндереп җибәрү** Тиз генә төзекләндерү; бераз төзекләндерү. *– Ул да йортны яңартып, дөньясын төзекләндереп җибәргән, – диде ул.* Кызыл таң

**Төзекләндереп калу** Төзекләндерергә өлгерү. *Йокы да әлләни эләкми, яшь чакта дөньябызны төзекләндереп каласы килә.* Кызыл таң

**Төзекләндереп кую** Алдан яки тиз арада төзекләндерү. *Без ача торабыз, реставраторлар матурлап төзекләндереп куя.* Р.Юныс. *Фикерләре ачык, белемнәре тирән, җанга үтеп керә, ватыкны-бозыкны төзекләндереп куя ала торган.* Ф.Яхин

**Төзекләндереп чыгу** Булган берсен рәттән төзекләндерү. *Туган авылы Мостафада Муса Җәлил музеен заманча төзекләндереп чыкканнар.* Ватаным Татарстан. *Күпкатлы бер йортны комплекслы төзекләндереп чыгу 8,6 миллион сумга төшә.* Шәһри Казан

**ТӨЗЕКЛӘНҮ** *ф.* Төзек хәлгә килү; яшәү һәм файдалану өчен уңайлы, яраклы хәлгә килү. *Ә Казаныбыз үзенең 1000 еллыгына әзерләнә, көннән-көн төзекләнә, матурлана.* Р.Миңнуллин. *Ә җитәкчеләргә авыл яши, төзекләнә кебек күренә торгандыр инде.* Г.Гыйльфанова

**Төзекләнә бару** Торган саен күбрәк төзекләнү. *Аллаһы Тәгалә вә табәрәкә хәзрәтләренең кодрәте илә мәмләкәтебез көннән-көн матурая, шәһәребез сәгатьләп төзекләнә бара.* Р.Батулла. *Петербург сыман, көннән-көн төзекләнә барды, чәчәк атты, ә төбәкләрдә төзелеш тыелды, бөтен мал-мөлкәт башкалада тупланды.* Р.Хәкимов

**Төзекләнә башлау** Төзекләнүгә таба бару. *Вакыт уза, яралар төзәлә, хуҗалыклар төзекләнә башлый, салам түбәләр тольга, калайга, шиферга әйләнә.* Туганайлар

**Төзекләнә төшү** Бераз төзекләнү, тагын да күбрәк төзекләнү. *Шартлар азрак төзекләнә төшеп, максатчан эзләнүләр дәвам итсә, калган өзекләрнең дә табылуы ихтимал бит.* М.Госманов. *Хәлбуки төзүчеләр бу сүз турында белешмә тупласалар, җыр үзе дә төзекләнә төшәр иде.* Р.Әхмәтҗанов

**Төзекләнеп бетү** Тәмам төзекләнү. *Бу көнне башкалага БДБ илләре җитәкчеләре килә башлый, һәм шәһәрнең барлык юллары шул көнгә төзекләнеп бетерелеп ачылачак.* Татарстан яшьләре. *Театр төзекләнеп беткәч, биредә бөтенләй яңача яшәеш башланачак, дигәннәр иде.* Ватаным Татарстан

**Төзекләнеп җиту** Тәмам төзекләнү, җитәрлек дәрәҗәдә, тулысынча төзекләнү. – *Урнашып беттегезме инде?* – *диде ул, әле һаман төзекләнеп җитмәгән каралты-курага күз йөгертеп.* З.Хәким

**Төзекләнеп калу** Нииндидер бер вакытка кадәр, үз вакытында төзекләндерергә өлгерү; нииндидер вакыйгадан соң төзекләнгән хәлгә килү. *Ярәмкә һәм Кәрәкәшледә үткән «Урам бәйрәмнәре»ннән соң авыллар төзекләнеп кала.* Кызыл таң. *Ләкин нәкъ менә шул капиталь ремонттан соң йортларның күбесе әллә ничә елга яшәреп, төзекләнеп калуын беркем инкяр итә алмас.* Ватаным Татарстан

**Төзекләнеп килү** Аз-азлап, акрын гына төзекләнү. *Сүз уңаеннан, Мәләкәс халкы хәзер язгы-көзге пычракларда батмый-чуммый гына яхшы юлдан йөрергә күнегәчәк, төзекләнеп килгән объектларга, урам чисталыгына да сөенә алачак.* Якты юл

**Төзекләнеп киту** Берара күзгә күренеп төзекләнү. – *Җырлый, – диләр, шулай кайвакыт Моңга тулып җаны шашып ала, Төзекләнеп китә һәр ватык.* Ф.Яхин. *Сабантуй алдыннан авыл тагын да матураеп, төзекләнеп китте.* Шәһри Казан

**ТӨЗЕКЛЕК** *и.* Төзек булу күренеше. *Күбрәк поляклар, австриялеләр күмелгән бу каберстандагы төзеклек, скульптура композицияләренең күплеге кешене тетрәндерерлек, гөнаһлы җирдә барыбызның да вакытлы икәнен сискәндереп искәртерлек, кешене күпмедер чистартырлык иде.* Н.Шәрифуллин. *Кайбер зур татар авылларының төзеклек, арулык ягыннан күршетирәләреннән нык аерылып торганы шикелле.* Р.Вәлиев

**ТӨЗЕКСЕЗ** *с.* Төзек булмаган, тәртипкә, рәткә салынмаган. *Бохараның урамнары тар, төзексез, таш җәелмәгән, яктыртылмаган, ә өйләре балчык, тәрәзәләре йорт эчендә.* Гасырлар авазы

**ТӨЗЕЛЕШ** I *и.* 1) Биналар, төрле корылмалар салу, кору эше. *Ул анда зур гына төзелеш җитәкчесенең юбилеена барган иде.* Ф.Садриев. *Суы үзе кипкәнме аның, әллә инде, зур төзелеш мәнфәгатьләрен күздә тотып, махсус киптерделәр микән?* Р.Низамиев

2) Бина, корылма салына торган, эш бара торган урын, мәйдан; корыла торган бина үзе. *Безнең төзелештә монтажниклар, штукатурчылар, электросварщиклар курсы бар, теләгәнеңә керергә була.* Т.Гыйззәт. *Сумкалы кеше «Казмашстрой» дигән зур төзелешкә эшчеләр туплый икән, хезмәт хакы әйбәт, эшчеләр өчен ашханә бар ---.* М.Мәһдиев

3) Биналар кору белән шөгыльләнә торган оешма. *Ул Ригада зур төзелеш начальнигы булган.* А.Хәсәнов. *Төзелеш идарәсендә Сабит турында «гариза язып эштән бөтенләй китте» дигәч, ул моңа аптырамады да бугай.* В.Имамов

**ТӨЗЕЛЕШ** II *и.* 1) Берәр предмет өлешләренең, кисәкләренең үзара урнашуы; предметның эчке корылышы, структурасы. *СТЗ-ХТЗ тракторының төзелеше, эшләнеше турында кулланма иде бу.* Ф.Сафиуллин

2) Нәрсәнең дә булса төзелү рәвеше; төзелү, оештырылу принциплары, системасы. *Галимҗан абый әйткән сүзләрне искә алып, чын поэзиянең һәм халык иҗатының тылсымлы үрнәкләре буенча шигырь төзелеше серләрен өйрәндем.* Х.Туфан. *Композицион төзелеше ягыннан пьеса ике өлештән тора.* А.Әхмәдуллин

3) Билгеле бер җәмгыятьнең, дәүләтнең оешу, төзелү тәртибе, системасы; строй. *Шундый авыр шартларда большевиклар партиясе илебез хуҗалыгын социалистик төзелеш юлына күчерүдә күпкырлы эш башлаган чор иде бу.* М.Мәһдиев. *Русия Конституциясе хакимият бүлешү принцибын Русиянең конституцион төзелеш нигезе итеп күрсәтә.* Татарстан яшьләре

4) *куч.* Берәр нәрсә барлыкка китерү, булдыру, оештыру эше. *Ул айлар, хәтта еллар буе кузгалмыйча түшәктә ятты, әмма халык һәм ил тормышын, социализм төзелеше сулышын тоеп яшәде.* Г.Ибраһимов. *Алар янәшәсендә колхоз төзелеше ветераннары Гыйльман абзый Гайнетдинов, депутат Хафиз абый Хәбибуллин да бар.* Т.Нәҗмиев

**ТӨЗЕЛЕШ-МОНТАЖ** *җый. и.* Һәртөрле төзү һәм монтажлау эшләре. *Ул, табель тутыру бүлегенә барып, үзенең цех эшчесе түгел, ә су эшләре төзелеш-монтаж идарәсеннән чакырылган ирекле бораулаучы икәнлеген исбат итәргә, начальнигы рөхсәте белән Каратаевның урынбасарына акланырга тиеш.* К.Кәримов. *Хезмәт юлын туган ягындагы зур оешмада төзелеш-монтаж эшләре мастеры булып башлап җибәрә.* Мәйдан

**ТӨЗЕЛМӘ** *с.* **1.** *лингв.* 1) Ясалма; берничә өлештән төзелгән, берничә сүздән, тамырдан һ.б. торган. *Бу юл белән яңа ясалган атамаларның бөтенесен – төзелмә терминнар дип, ә аларның төрләре ясалма, кушма, парлы, тезмә һәм кыскартылма терминнар дип атап йөртү күрсәтелә.* М.Әнвәрова

2) *мат.* Бүлүчеләре икедән артыграк булган, натураль (сан тур., мәс., 21, 27, 33, 39); *русчасы*: **составное число**. *Төзелмә сан*

**2.** *и. мәгъ.* 1) *лингв.* Грамматик бәйләнешләре ягыннан карала торган сүзләр тезмәсе. *Иярченле кушма җөмләләр дә татар телендә гаять катлаулы төзелмәләрне тәшкил итә.* И.Бәширова. *Шуңа да мондый төзелмәләрне шартлы рәвештә, бары формаль яктан, сөйләм дәрәҗәсендәге парлы сүзләр итеп кенә карап була, алар телнең яңа берәмлеген тәшкил итә алмый.* Р.Мөхиярова

2) *лингв.* Билгеле авазлар тезмәсе. *Аваз төзелмәләрен түбәндәге тәртиптә карыйлар: сузыклардан торган төзелмәләр, сузыклар белән тартыклардан торган төзелмәләр һәм тартыклардан торган төзелмәләр.* Татар грамматикасы

**ТӨЗЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **төзү**. *Шәһәрдә зур храмнар, театрлар, сарайлар, мунчалар төзелә.* М.Мәһдиев.

*Берзаман безгә җитәкчеләр өчен махсус төзелгән яңа йорттан фатир бирделәр.* М.Маликова

**Төзелә бару** Торган саен күбрәк төзелү; эзлекле рәвештә төзелү. *Голҗада күпме каберлекләр күчерелеп, дистәләгән зират өстендә яңа йортлар төзелә бара.* Р.Гыйлемханов. *Һава Кирмәне, ап-ачык булып, Суфия белән Кырмыска алдында үсә, төзелә барды.* С.Гаффарова

**Төзелә башлау** Бераз төзелү. *Мәчет төзелә башлагач, йөзләрчә кеше хәл кадәренчә үз өлешен кертергә ашыкты.* Т.Миңнуллин. *Әнә шуңа күрә, илдә күмәк хуҗалыклар төзелә башлагач та, Халит беренчеләрдән булып «Кызыл көрәш» колхозына керә.* Т.Нәҗмиев

**Төзелә килү** Күптәннән бирле, акрынлап, аз-азлап төзелү. *Акрынлык белән булса да, уку йортларында татар әдәбиятын укыту өчен программалар, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр эшләнә һәм төзелә килә.* А.Әхмәдуллин. *Документ, рәсми кәгазь, төрле язма атамалары, эш кәгазьләре стиле безнең халкыбызда күп гасырлар буе иске татар телендә төзелә килгән.* Р.Мөхиярова

**Төзелә тору** Әледән-әле, даими төзелү. *Хәер, йорт-утар төзелә торсын, без исә, бер-ике сүз белән генә булса да, күп мәртәбәләр телгә алынган шәһәрне беркадәр тасвирлап үтик.* Л.Хәмидуллин. *Заводлар төзелә тора, ә кибетләрдә адәм баласына кирәкле әйберләр артамы?* М.Галиев

**Төзелеп бетү** Төзелү эше тәмамлану. *Гасыр башында төзелеп беткән бу бинаның кыяфәт-рәвешен башта кәгазьдә, аннары гамәлдә иҗат иткән шәхеснең исемен тарих онытмаган.* М.Галиев. *Без туктаган авыл төзелеп бетүгә, хуҗалык башта игенчелек белән шөгыльләнеп карый.* Н.Гариф

**Төзелеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә, билгеле күләмдә төзелү. *Сарай төзелеп җиткәнче, килгән чакта патшага тукталыр өчен кечкенә генә йорт та җиткергәннәр.* С.Зыялы

**Төзелеп килү** Соңгы вакытта азазлап, акрын гына төзелү. *Зур тәрәзәләр аша яңа төзелеп килә торган шәһәр панорамасы күренә.* Т.Гыйззәт. *Ягымлы, чәчәкле стильне салкын, коры сүз куерту алыштырган, нәтиҗәдә әсәр төзелеп килә торган күркәм йортның түбәсен вакытлыча камыш белән ябып торуга охшап киткән.* Ф.Хатипов

**Төзелеп тору** Әле, хәзер төзелү; төзелү процессында булу. *Аларның әледән-әле яңалары төзелеп тора, искеләре картая, хәтсезләре, ни кызганыч, таркалып юкка чыга.* Н.Шәфигуллин. *Русиянең бик күп төбәкләреннән аермалы буларак, бездә һәр ел саен яңа мәктәпләр, балалар бакчалары төзелеп тора, искеләренә, авырлык белән булса да, әкренләп ремонт ясала.* Р.Вәлиев

**Төзелеп яту** *сөйл. к.* **төзелеп тору**. *22 урында салына башлаган авылларның бүгенге көндә 17се уңышлы рәвештә төзелеп ята.* З.Зәйнуллин. *Ләкин алар берсе дә куян комплексы өчен түгел, барысы да төзелеп ята торган сыерлар комплексы өчен ташыла иде.* В.Нуруллин

**ТӨЗЕМ** *и.* **1.** 1) Эчке төзелеш; эчке төзелү рәвеше, строй. *Төрле сыйныфларыбыз, төркем һәм кабиләләребез хәзерге көндә, һич булмаса, вакытлыча, ягъни яңа төзем нигезләре салынганчы, үзләренең мөһим булмаган файдалары һәм җирле мәнфәгатьләре турында онытып торырга тиешләр...* Г.Исхакый

2) *сир.* Төзелеш, төзү эше; архитектура. *Бу чорда ул инде – корым-төзем эшләрендә яхшы ук тәҗрибә алган, классик һәм милли төзем формаларын нык үзләштергән белгеч.* Б.Урманче

3) Билгеле бер тәртиптә төзелгән, билгеле бер төркемгә тупланган нәрсәләр; төзелмә. *Менә шушы кешеләрнең төркемләшүләре белән бергә, югарыда күрсәтелгән, түбәндә бөтен кешелек өчен уртак аваз комплексларыннан гыйбарәт булып та, соңыннан, кешеләр төркемләшә башлагач, һәр төземдә үзләренә тышкы аерымлык алып өлгергән әлеге дүрт төп элемент та үзара катнаша башлыйлар.* Х.Бәдигый

**2.** *с. мәгъ.* 1) *диал.* Тигез; чокыр-чакырсыз. *Французларның атлары Төзем җирдә дулыйдыр; Кутузовның казаклары Дошманнарны турыйдыр.* Бәет

2) Әйбәт, яхшы, төзек. *Бер мәкаль куәтли минем бу сүзне (Ишет һәм эшкә тот, и, холкы төзем) ---.* Й.Баласагуни

**ТӨЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* Төз хәлгә китерү, төзәйтү. *Матурлыктан өстен көч юк: күккә аштыра, тезләндерә, хәнҗәрлегә гөл алдырта, бөкрене төзләндерә.* Р.Фәйзуллин

**ТӨЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Төз хәлгә килү, төзәю. *«Полковник» дигәндә, гәүдәсе турайды, иңбашлары төзләнде.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Төзек, матур, тәртипле хәлгә килү; яхшыру, матураю. *Ил-йортларың төзләнгән, Сылу кыздай бизәнгән ---.* М.Ногман

**Төзләнеп китү** Кинәт, ниндидер сәбәпләр яисә нәрсәнеңдер тәэсире аркасында төзләнү. *Кульъязма шигырьне машинкада бастырып алсаң, ул ничектер әйбәтләнеп, төзләнеп киткән кебек була.* Р.Харис

**ТӨЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Төз итү, төзәйтү; турайту, тигезләү. *Ишелеп төшкән авырлыкларны бар сынны катырып һәм тез буыннарын калтыратмыйча күтәрмәгәч, ялганнарны, бармаклар каната-каната, кәкре кадак төзләгән шикелле турыламагач, мактауларга, ялагайлануларга өстән карамагач, рәнҗетүчеләрдән үч алмагач, яшәү яшәүмени ул?!* Ә.Гаффар

2) *иск.* Билгеле бер предметка туры итеп юнәлдерү, төзәү; төбәү. *Бер күреп бәхетем кошын, Кулга төшерергә теләп тә, байтак уклар төзләдем.* К.Нәҗми

3) *күч.* Яхшырту, тәртипкә салу. *Син әрәм бул, кер кабергә! Дөнья калсын яхшыга, Син үзең кит, төзлә җирне, яхшы берлән яхшы да!* Ф.Ибраһимов

**Төзләп алу** Тиз генә төзләү. *– Беренче мәртәбәдән булмый әле ул, – диде ул тешен кысып. – Төзләп аласы булыр [савытны].* Көмеш кыңгырау

**ТӨЗЛЕК** *и.* Төз булу сыйфаты. *Картаелыр, күзнең угы сыныр, кан суына төшәр, төзлек бетәр, текә горурлык яссылана төшәр.* Р.Фәйзуллин. *– Аякларым кәкре түгел, алар бары төзлекләренә чыдый алмаганга гына кәкрәешеп торалар, – ди иде безнең күрше авыл егете.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ТӨЗҮ** I *ф.* 1) Аерым өлешләрдән, кисәкләрдән, материаллардан зур корылмалар, биналар һ.б.ш. кору, салу, ясау. *Без гигант заводлар, гигант фабрикалар төзибез.* Һ.Такташ. *Җәүһәр, авылны чүплеккә эттереп, урынына шәһәр төзиләр икән, дигән сүзгә башта ышанмыйчарак торды.* Ф.Җамалетдинова

2) Нинди дә булса төркем, коллектив оештыру; кешеләр туплау. *Менә, мәсәлән, җирле халыктан полиция отрядлары төзиләр, тот та шунда кер.* Т.Гыйззәт. *Берничә сәгать җил-яңгыр астында басып торганнан соң, немец сакчылары, әсирләрнең тазаракларын сайлап алып, эш командасы төзиләр.* Р.Мостафин

3) *махс.* Мөстәкыйль элементларны кирәкле тәртиптә бер-беренә тоташтырып, вакытлыча нәрсә дә булса оештыру; кушып тору, тезеп ясау. *Хәзер вагоннарны бергә җыеп, эшелон төзергә һәм юлга чыгарга тиешле.* Х.Камалов

4) Нинди дә булса мәгълүматны, материалны (фәнни, әдәби, фактик, сөйләм һ.б.ш.) сайлап алып, билгеле бер тәртипкә китереп оештыру, язу, бербөтен нәрсә иҗат итү. *Җ.Вәлиди, татар лексикографиясе тарихында беренчеләрдән булып, картотека нигезендә фәнни юл белән сүзлек төзү эшен башлап җибәрә.* Ш.Асылгәрәев. *Ике сүздән бер җөмлә төзи белсә, ул инде гәзит-журналларның иң актив авторына әйләнә, «фәлсәфи» трактатлар яза башлый.* Р.Миңнуллин

5) Берәр эш, үзара мөнәсәбәт һ.б.ш. турында рәсми рәвештә, кабул ителгән тәртиптә сүз куешу, килешү. *Анда, загста язылыр алдыннан, никах килешүе төзиләр икән.* М.Маликова. *Италиянең әлеге шул Новара шәһәренә барып, тәрәзә рамнары гына түгел, ишекләр чыгару буенча да яңа контракт төзеп кайта.* Р.Корбан

6) *мат.* Бирелгән күләм, шартлар, үлчәү һ.б.ш. нигезендә математик гыйбарә оештыру яки геометрик фигура сызу. *Бер түбәсе (0, 0) ноктасында урнашкан, ике түбәсенең торышын кулланучы үзгәртә ала торган өчпочмак төзергә кирәк.* Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе. *Тигезләмә төзү*

7) *күч.* Иҗтимагый характердагы берәр нәрсә оештыру, кору, булдыру. *Беренче этап – Россиядә демократик республика төзү.* М.Мәһдиев. *– Әле генә корылтай Вакытлы хөкүмәт төзү турында карар чыгарды, – дип, ул соңгы хәбәрне җиткерде.* М.Әмирханов

**Төзеп алу** Тиз арада төзү. *Гейзерих король Атилла хан белән солых төзеп алды да Карфагенга кадәр барып җитте.* М.Хәбибуллин. *Син – фәлән авылга, мин фәләненә барам дип, график төзеп алдылар.* Безнең гәҗит

**Төзеп бетерү** Төзүне тәгәлләү; төзелгән хәлгә китерү. *Үзенең башлаган нәрсәсен төзеп бетермичә, башкаларга күрсәтми.* Ф.Яруллин. *Менә көзгә коттеджны төзеп бетерәм, квартирны малайга калдырып, үзебез шунда күчәргә җыенабыз.* Аманулла

**Төзеп бирү** Кем өчендер төзү. *Яшьләрне качырмас өчен, авыл саен катлы-катлы клуб, спорт сарайлары төзеп бирер идең, кая ул?* В.Имамов. *Балаларны институтка кертәсе бар, эшкә урнаштырасы, дачасын төзеп бирәсе, машинасын-фатирын юнәтәсе, һичьюгы, фатирдагы бала-чагаларга күз-колак булып торсаң да файда.* К.Кәримов

**Төзеп йөрү** Озак вакыт дәвамында төзү. *Шул Татбригада белән совет хөкүмәтен төзеп йөргән картлар, инвалидлар Җәләлабад базарын тутырып утыралар.* Б.Урманче

**Төзеп килү** Акрынлап төзү. *Буш даланы кишәрләргә бүлеп, урам-урам шәһәр төзеп киләләр.* Ф.Бәйрәмова. *Бер ягыннан төзеп киләләр, икенче яктан җимерелеп бара.* Р.Вәлиев

**Төзеп кую** Алдан төзү; төзелгән хәлгә китерү, тиз арада төзү. *Сәлим хан вакытында чарасын күрмәсә, әмир үзенә бер дәүләт тә төзеп куяр.* М.Хәбибуллин. *Шул ук кичне институтны бергә тәмамлаган курсташлар белән төшкән фотоальбомны алып актардык һәм кунакларның исемлеген дә төзеп куйдык.* Д.Гыйсметдин

**Төзи башлау** Төзергә тотыну. *Ярлы колхозның җирләрен алып, исәпсез-хисапсыз төрле йортлар, биналар, гаражлар, цехлар төзи башладылар.* З.Мәхмүди. *Алар талантлы, сәләтле, эш сөйгән һәм эшли белә торган шәхесләрне үзләре теләгәнчә яшәтеп, аларны сүзсез, каршы әйтми торган хайваннарга әйләндереп, яңа вазгыять, яңа хакимият, яңа ил төзи башлыйлар.* З.Зәйнуллин

**Төзи тору** Һаман төзү. *Әйе, барып гыйбадәт кылучылар кайбер очракларда бармак белән санарлык кына булса да, без аларны төзи торабыз.* Н.Шәрифуллин

**ТӨЗҮ** II *и.* 1) Төзү эше; төзүчелек осталыгы. *Төзү эшенә өйрәнү*

2) Төзелеш, нәрсәдер төзелә торган урын һәм төзелә торган объект үзе. *Ясалма оҗмах тәмам төзелеп беткәч, аллы-гөлле утлар да кабынгач, төзүдә эшләгән кавемне кабат сәкарьгә [җәһәннәмгә] тутырырга боергач, Ата Шайтан, Генеральный Иблискә рапорт бирү нияте белән, кабат кантурына керде.* Ф.Баттал. *Ул вакытта бөтен яшьләр төзүдә эшләдек.* Хезмәт даны

**ТӨЗҮ-МОНТАЖЛАУ** *җый. и.* Төзү һәм монтажлау эшләре. --- *гаражлар, заправка, техник хезмәт күрсәтү станциясе, төзү-монтажлау участогы --- төзеткәндә, балта остасы, электрик, төзүче һөнәрләрен энәсеннән-җебенә кадәр белү дә, төзелеш оешмасында бергә эшләгән танышлар да төп ярдәмчегә әйләнә.* А.Әхмәтгалиева. *Төзү-монтажлау, кагыйдә буларак, җәйге чорда башкарыла, чөнки җир һәм бетон эшләре белән бәйле.* Безнең гәҗит

**ТӨЗҮЧЕ** *и.* 1) Биналар, корылмалар һ.б.ш. нәрсәләр салу, кору белән шөгыльләнүче кеше; төзелеш тармагында эшләүче кеше. *Рафис – агроном, Фәнис – төзүче, Рәсимә – хисапчы, Ләйсирә – табиб: һәрберсенең киләчәккә максаты ачык һәм билгеле иде.* Г.Галиева. *Төзелеш батальонында хезмәт итү егеткә киләчәк тормышында һөнәр сайлауда ярап куя: ул төзүче булырга карар кыла.* Р.Корбан

2) Мөстәкыйль элементлардан вакытлыча төзелмә ясаучы, тезүче, оештыручы кеше. *Машинистлар, поезд төзүчеләр, диспетчерлар арасыннан,*

*тиз генә күз йөртеп, Галимҗан абыйны эзлим.* Л.Ихсанова

3) Кешеләр төркеме, коллектив туплаучы, җыючы, оештыручы кеше. *Икеөч көннән үк аның әшнәсен, транспорт командасына кертеп, Бухенвальдтан бөтенләй озаттылар, ә «отряд» төзүче кеше үзе яңадан 44 нче блокта күренмәде.* Г.Әпсәләмов

4) Төрле фактик, фәнни, әдәби һ.б.ш. материалларны сайлап алып, аларны билгеле бер тәртиптә җыючы, язучы, туплап бирүче кеше. *Ул өлеше төзүче тәрҗемәсендә бирелә.* Г.Кутуй. *Әйтик, Хәләф Гарданов – язучы һәм дәреслекләр төзүче, Шәриф Сайкин – дәреслекләр, диктантлар авторы.* Ф.Ярullин // Нинди дә булса рәсми һ.б.ш. документларны, кәгазьләрне тутыручы, язучы. *«Ике ел», – диде «дело»ны төзүче яшь кенә лейтенант.* Х.Камалов

5) *күч. юг.* Иҗтимагый характердагы берәр нәрсә оештыруда катнашучы; яңа караш, иҗади акыл белән нинди дә булса матди яки рухи байлыклар һ.б.ш. тудыручы, барлыкка китерүче кеше. *Совет заманында ул ачык иде: коммунизм төзүче, тормышка яңалык кертүче, ватанпәрвәр.* Ю.Сафиуллин. *Алар искегә киртә куеп, яңа тормыш төзүче, чорның яңа геройлары, киләчәк кешеләре булып алга килеп басалар.* Г.Фәйзрахманова

**ТӨЗҮЧЕЛЕК** *и.* 1) Зур, катлаулы корылмалар, биналар төзү тармагы, төзүче (*1 мәгъ.*) һөнәре. *Диплом яклар вакыт җиткәч, төзүчелекне ташларга туры килде.* Р.Батулла. *Төзүчелек дәрте Туфанга шул көннәрдә иңгәндерме, белмим, үзем шаһит булган 30–40 ел дәверендә мин аның нәрсәдер кормыйча, нәрсәдер төземичә торган чагын хәтерләмим.* Р.Вәлиев

2) Төзелеш; төзү эшләре. *Дүрт мең ярымнан артык эшкә яраклы кешене гадәти игенчелек, терлекчелек, төзүчелектә генә файдаланып бетерү, димәк, мөмкин түгел.* Т.Әйди. *Ирем Кәрим хәзерге вакытта төзүчелек өлкәсендә эшләсә дә, күңеле иҗатка тартыла.* Идел

**ТӨЙГЕЧ** *и.* 1) Җирне яки берәр каты нәрсәне төеп тыгызлау өчен, бер очы юанрак һәм йомрырак булган тимер яки агач таяктан гыйбарәт эш коралы. *Үзе белән балта, көрәк, пычкы, чүкеч, кыскыч, төйгеч, кискеч һәм башка кораллар алды.* А.Хәлим. *Бу минутта алар да, мөгаен, шулай көлешәкөлешә, Инсафлар салып киткән юлны тәртипкә китерәләрдер: махсус төйгечләр ярдәмендә, шпал кымшанмаслык хәлгә килгәнче, ян-якларындагы вак ташны дыңгычлыйлардыр.* Ф.Абдуллин

2) Аш-су әзерләгән вакытта, пешкән бәрәңге һ.б.ш. изү, төю өчен кулланыла торган әсбап; тукмак. *Әшен ул башта тормыш-көнкүрештә еш кулланыла торган уклау, куна тактасы, төйгеч кебек гади әйберләр ясаудан башлый ---.* Яңа тормыш. *Кайнап чыккан сөткә эремчекне салып, тишекле төйгеч белән яхшылап изеп болгаталар.* Мәдәни җомга

3) *к.* **киле**. *Кешеләрнең бер өлеше иген иккән, китмәнле игенчелек үсеше хакында каберләрдә табылган орлык төйгеч һәм тары ярмасы калдыклары сөйли.* Б.Хәмидуллин. *Музейда орчык, балык тоту кораллары, таш чүкеч, чүлмәк ватыклары, ашлык төйгеч, бөртек саклау савыты һәм башка җиһазлар саклана.* Байрак // Аш-су пешергәндә борыч, яшел тәмләткеч һ.б.ш. төю өчен кулланыла торган махсус савыт; кечкенә киле. *Берничә бөртек дөгене төйгечтә төеп карау да җитә.* Туган як

4) *к.* **кисап**. *Төйгеч белән киледә борыч төю*

**ТӨЙГЕЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр көпшәгрәк массаны махсус төйгеч, тукмак һ.б.ш. нәрсә белән төеп тыгызлау. *[Корбанов], трубкасына тәмәке тутырып, аны төйгечләде, ут кабызды.* Г.Ахунов

2) Җиргә, өслеккә каты басып йөрү, таптау. *Табан эзләре арасын ат тоягы аяусыз төйгечли, бу ерымны сукмак итеп кешеләр дә таптый.* М.Хуҗин. *Өстәвенә балалар укыта, --- мәҗлесләрдә ай-һайлап җырлап җибәрә, агач аягы белән идәнне төйгечләп биергә төшеп китә.* Кызыл таң

3) Нәрсәне дә булса берәр әйбергә бик нык тыгызлап тутыру. *Карт трубкасын бармагы белән төйгечли, ашыкмыйча гына, җитди итеп сөйли ---.* М.Мәһдиев. *Чалбары галифегә охшап кабарып торсын өчен, ике кесәсенә дә, төйгечләп, чүпрәк тутырган.* М.Галиев

4) Нәрсәгә дә булса кат-кат сугу, шаку, бәргәләү. *Ул тагы, тагы, берсеннән-берсе көчлерәк итеп, йодрыклары белән стеналарны төйгечләргә тотынды.* М.Кәбиров

5) Берәр кешене яки хайванны кыйнау; кат-кат сугу. – *Ә сине, – ул уклауны тагы да ныграк батырды, – шушы нәмәстәңне төйгечләп, йолкыш эт итеп йорттан чыгарып җибәрәм!* Т.Гарипова

6) *сөйл.* Берәр нәрсәгә кертү, яру, җимерү, каты әйбер белән кат-кат сугу, кагу. *Безнең кызлар шикелле, анда көн саен чи усак түмәркәсен калун белән төйгечләп азапланмыйлар.* М.Мәһдиев

7) *күч.* Күп туплау, сыйдыру (абстракт төшенчәләр тур.). *Әллә бу сугыш елларында муен нечкәргән, әллә еллар буе белем төйгечләп баш авырайган: ни хикмәттер, аска төшә дә китә баш, төшә дә китә.* М.Мәһдиев

◊ **Төйгечләп тутырылган** Бик тулы, бик күп, шыгрым тулы. *Төйгечләп тутырылган халыкны күргәч, куркып киттем.* Ә.Еники. *Тарих төпкеленә төйгечләп тутырылган халык җаны, милләт рухы, бәлки, бүген поэмалар ургылы булып атыладыр?* Н.Сафина

**Төйгечләп алу** Кыска вакыт аралыгында төйгечләү. *Юлда туктыйтуктый, боксёрларча хәрәкәтләр ясап, һаваны төйгечләп алгалады.* М.Галиев

**Төйгечләп бетерү** Төйгечләүне тәгәлләү; барысын да төйгечләү. – *Төйгечләп бетер инде, буш урын калмасын, – дигән иде ул, чыгып киткәндә.* Мәйдан

**Төйгечләп килү** Озак вакыт дәвамында төйгечләү. *Мескен татар теленең сул як кабыргасын әллә ничә гасырлар буе гарәп йодрыгы төйгечләп килде.* С.Поварисов

**Төйгечләп кую** Алдан төйгечләү; төйгечләнгән хәлгә китерү. *Тәмәкесен төйгечләп куйды да ашыкмыйча гына сүз башлады.* М.Галәү

**Төйгечләп ташлау** *сөйл.* Тиз арада төйгечләү, кинәт төйгечләү. *Исерек килеш күршесен дә төйгечләп ташлаган, тик үзе боларны хәтерләми ---.* Кызыл таң

**Төйгечләп тору** Даими, һәрвакыт төйгечләү; хәзерге моментта төйгечләү. *Аның миен тик бер генә уй төйгечләп тора иде: кызыллар килеп басмас борын, Ирьегетне алып чыгып китәргә.* Н.Мусин

**Төйгечләп чыгу** Барысын да рәттән төйгечләү. *Өскә калкып тормасын өчен, йодрыгы белән төйгечләп чыкты, аннары читтәге кыяк төпләреннән чирәм кисәкләре кубарып алып, «кабер» өстенә түшәде.* Ш.Маннур

**Төйгечли башлау** Төйгечләргә тотыну. *Ишеккә якын торган өч стражник, каушап китеп, ясалганнан бирле кайрак күрмәгән үтмәс кылычларын чыгарып маташканда, аларны да төрле куллар бөтереп алып, каты-коты әйберләр белән төйгечли башладылар.* М.Галәү

**ТӨЙДЕРҮ** *ф. диал. йөкл. юн. к.* **төю** II. *Кырык төенме төйдердең, Катып бирдеңме я ашка?* Г.Кандалый

**ТӨЙМӘ** *и.* 1) Сәдәф, металл, агач, пластмасс яки башка нәрсәдән ясала һәм киемнең ерылган урынын каптырып кую яки бизәү өчен кулланыла торган каптырма. *Ул өч билле тунны һәм, казаки кебек, алдан биш төймә, алты төймә белән төймәлиләр.* К.Насыйри. *Башына аның ак кәҗә мамыгыннан бәйләнгән йомшак йонтәс башлык, өстенә бик зур ике кара төймә белән каптырылган кыска гына карасу сырма кидерелгән иде, аякларында исә өр-яңа нәни генә кызгылт чүәк иде.* Н.Фәттах

2) Счёт, тәсбих кебекләргә тезелгән кечкенә түгәрәкләрнең берсе. *Тәсбихтә 99 төймә була.* Н.Фәттах. *Шалт-шолт чут төймәләрен сала-сала, кыз кинаягә киная белән җавап кайтарды: – Хисапчының бар белгәне дебет, кредит инде аның, Мөнирҗан.* Н.Әхмәдиев

3) Өстенә бармак белән басып сигнал бирү, төрле механизмнарны кабызусүндерү яки хәрәкәткә китерү өчен хезмәт итә торган җайланма, кнопка, клавиш. *Һәр кешенең өстәлендә төймә, шул төймәгә бассаң, ут бары тик синең алны гына яктырта.* Р.Батулла. *Вилдан үзе шалт та шолт радиоалгыч төймәләренә баса, уйларының очына чыга алмый.* М.Маликова

4) Уен коралларында (мәс., баянда, гармунда һ.б.) өстенә бармак белән басып аваз яңгырату өчен көйләнгән кечкенә пластинка, клавиш. *Бу минутта ул үзен патша тәхетендә утырган кебек хис итте, Искәндәр баян төймәләренә кагылуга, җырлар-биюләр башланды, мәҗлестәгеләргә күрше бүлмәдәге студентлар да килеп кушылды.* Р.Вәлиев. *Гармунның төймәләренә саннар язып чыкканмын.* Р.Миңнуллин

5) Җимешле агачларда чәчәк койганнан соң җимшән урынына хасил булган җимешнең яшь, өлгермәгән яралгысы. *Иван Ивановичның кадерлесе әнис алмасында нибарысы егерме җиде яшел төймә яралды.* А.Гыйләҗев

6) Мәрҗән, таш, пыяла, агач һ.б.ш. шундый нәрсәләрне җепкә тезеп ясалган бизәнү әйбере; муенса. *Төймә җебе әллә инде черегән булып чыкты, әллә начар бәйләнгән иде: күз яшедәй гәрәбәләр бүлмә буйлап чәчелде.* Н.Әхмәдиев. *Таң чыклары сәйләнем, Төймә итеп бәйләдем.* Г.Сабитов

7) Кечкенә түгәрәк формасындагы дару; таблетка. *Мин аңа сызлауны бераз баса торган ике төймә бирдем.* А.Хәсәнов. *Кыз, ят, сәер тавышлар белән такмаклый-такмаклый, калтыранган куллары белән шешәдән берничә ак төймә алды һәм аларны тиз генә йотып та җибәрде.* Ф.Бәйрәмова

8) Кечкенә яссы түгәрәк формасындагы теләсә нәрсә. *– Нәкъ чын чәчәк төсле, таҗында чык тамчысы да җемелдәп тора, ә исе, – ул савытның төймәсен борып алып иснәде: – Дим тугайларының исе бар.* Г.Әпсәләмов. *Сайгушев, ишектән ялт кереп, йозакны бикләп тә куйды, бу йортта булганы бар һәм йозак төймәсен кайсы якка борасын электән белгән кебек иде аның хәрәкәтләре.* М.Хуҗин

◊ **Төймә генә төйми инде** Булдыклы, кулыннан теләсә нинди эш килә торган, оста куллы кеше турында. **Төймәдән дөя ясау** Берәр нәрсәне бик нык арттырып, күпертеп күрсәтү, сөйләү; вак, әһәмиятсез нәрсәгә артык зур игътибар бирү. *Төймәдән дөя ясап йөргәнче, кайтып ял ит, я җаның чыгып китәр.* Ф.Яруллин. *Тагы нәрсә булды икән, нинди төймәдән дөя ясарлар икән, диган уйлар зиһендә чагылып китә.* Х.Камалов. **Төймә кебек** 1) Кеп-кечкенә, вак. *Аның төймә кебек бәләкәй генә зәңгәрсу күзләрендә әллә мыскыллау, әллә шаяру белдергән нindидер очкын ялтырап китте.* Н.Фәттах; 2) Сау-сәламәт, матур, тере, хәрәкәтчән бала турында. *Төймә кебек балам.* **Төймәне дөя (тәвә) итеп күрсәтү** *к.* **төймәдән дөя ясау**. *Мәзкүр журналның төймәне тәвә итеп күрсәтеп язган мәкаләләреннән бәгъзыларын газетабызда тәрҗемә кылырбыз.* Г.Камал. **Төймәне дөя итү** *к.* **төймәдән дөя ясау**. *Рус җәмәгатьчелеге алдына Г.Фәйзи, Ш.Рәхмәтуллинны китереп утыртып, Г.Камалларны хәтердән чыгару – бу – музейга кереп филне күрмәү, әмма әһәмиятсез төймәне дөя итү буладыр.* Г.Ибраһимов. *Көнче төймәне дөя итә.* Х.Камалов

**ТӨЙМӘБАШ** *и. бот.* 1) *к.* **күкчәчәк**. *Көтүлектә соң чәчәк атучан көзге гөлбаба (кульбаба осенняя), меңьяфрак (тысячелистник), болын төймәбашы (василёк луговой), каклавыч (бодяк) кебек начар ашалучан үләннәр көтүлекләр өченче һәм дүртенче кат файдалангач чабылалар.* Агулы үсемлекләр

2) *к.* **кашкарый**. *Төймәбашлар июньдә чәчәк ата*

**ТӨЙМӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төймәләү**. *Портретлары менә болай: ире капрон эшләпә кигән, күлмәгенең якасы күкрәккә кадәр ачык, пиджак төймәләнмәгән, зур корсагы салынып, күлмәкнең аскы сәдәбе ычкынган.* М.Мәһдиев. *Аскы сәдәбе генә төймәләнергә җайланган пиджагын бик иркәләп, яратып чөйгә элеп куйды.* Т.Галиуллин

2) *бот.* Бөреләнү, бөртек, төймә (5 мәгъ.) барлыкка килү. *Кабарып торган ямь-яшел үлән, кайсы чәчкә аткан, кайсы төймәләнгән яшь чәчкәләр тугайга сыеша алмый торалар.* Ф.Вәлиев. *Хәзер агрономнар да чапкычларга элекке кебек ашыгып тотынмыйлар, киресенчә, чәчәкләрнең орлыкка төймәләнүен көтәләр.* М.Зарипов

3) *куч.* Төймә рәвешенә керү, түгәрәкләнү, йомрылану. *Аның белән бергә*

*чачакланган, чачакларына аяк җылысыннан төймәләнеп кар сарган иске чабаталары да, чаңгыларының нәфис итеп уелган, сыртларына нимес хәрефләре белән «Viktoria» дип язылган очлары да --- талпына ---.* А.Хәлим. *Тамчыларның төймәләнеп, тамар чагы да җиткән икән инде әнә.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Барлыкка килү, ялалу (хис-тойгы тур.). *Кемгә икәнен дә белмәстән, аның күңелендә рәнҗү-үпкәләү шикелләрәк бер нәрсә төймәләнде.* Р.Низамиев

**Төймәләнә башлау** Төймәләнергә тотыну; төймәләнгәне күренү. *Чәчәкләр бөрегә төймәләнә башлаган*

**Төймәләнә төшү** Тагын да бераз төймәләнү

**Төймәләнеп бетү** Барысы да төймәләнү, тулысынча төймәләнү. *Тормышяшәеш ваклыкларыннан Әхмәт өстен: галстугының дөрес төенләнешенә, күлмәк якасының тәгаен ятуына, кәстүм сәдәпләренең төймәләнеп бетүенә игътибар итмәс.* Т.Галиуллин

**Төймәләнеп килү** Әкренләп төймәләнү; төймәләнүгә таба бару. *Өлкән Сәгыйрь инде чәчәге коелып, төймәләнеп килгән алмаларга карады.* М.Галиев. *Авырттырган, төн йокыларын качырган, берьюлы ачы да, татлы да тоелган могҗиза төймәләнеп килә түгелме?* Р.Низамиев

**Төймәләнеп тору** Төймәләнгән хәлдә булу; төймәгә охшап тору. *Зур коңгырт күзләре, алсуланып торган йомшак тәне, төймәләнеп торган пөхтә борыны, йомрыланып килгән колаклары, гел елмаеп торучы нәфис иреннәре, иң мөһиме – малайның койрыгы бөтенләй дә булмавы барлык торалкай халкын чыгырыннан чыгара иде.* Көмеш кыңгырау

**ТӨЙМӘЛӘ́Ү** *ф.* Төймәләрне (*1 мәгъ.*) эләктерү, каптыру. *Профессор халат төймәләрен бик озак төймәләде, һаман аның бер чабуы озын, икенчесе кыска булып чыга иде.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин ыңгырашудан тиз туктый ул, чөнки өстәл янына чандыр, төз гәүдәле, погонсыз кителен ияк астына кадәр менгереп төймәләгән, төкле яңаклы, ябык битле коры бер ир утыра.* М.Мәһдиев

**Төймәләп бетерү** Барысын да төймәләү, барысын да төймәләнгән хәлгә китерү. *Икенче балак та артык карышмагач, чалбарын төймәләп бетергәч, әти кеше, күкрәген тотып, диванга утырды ---.* Ә.Баян. *Чалбарын урам буйлап йөгергәндә төймәләп бетерде.* М.Мәһдиев

**Төймәләп җибәрү** Тиз генә төймәләү. *Пәлтәңне төймәләп җибәр*

**Төймәләп кую** Төймәләнгән хәлгә китерү. *Сакалын учлады, куе зәңгәр җирлеккә нечкә генә ак сызыклар сызылган өр-яңа костюмының төймәләрен берсен дә калдырмыйча төймәләп куйды.* Г.Ахунов. – *Чукынчык! – диде ул. – Ашыгычлык белән төймәләп куярга да онытылган.* Р.Сибат

**Төймәләп тору** Сөйләү моментында төймәләү. *Шмит, сүзләренең тәэсирен белү өчен, сырмасының җиң очларын төймәләп торган Фатыйманы дикъкать белән күзәтте.* А.Расих. *Курткамны киеп, сәдәфләрен төймәләп торганда, рәсемен тәгаенләп килгән художник кыяфәтенә кереп, ияген учлап, бик ныклап һәр хәрәкәтемне күзәтте.* Р.Рахман

**Төймәләп чыгу** Берсен дә калдырмыйча төймәләү, барысын да берәмберәм төймәләү. *Башта ул ашыкмыйча гына халат төймәләрен төймәләп чыкты, аннары, иннеген алып, күзге янына юнәлде.* Кызыл таң

**Төймәли башлау** Төймәләргә тотыну. *Кияргә ярдәмен тәкъдим итү өчен үрсәләнгән Сабир Кәшфиевичкә мөмкинлек бирмичә, төймәли үк башлады.* Ф.Яхин

**Төймәли төшү** Тагын да күбрәк төймәләү. – *Күлмәгеңне төймәли төш әле, бигрәк ерык, – дип калды апасы аның артыннан.* Р.Вәлиева

**ТӨЙНӘГЕЧ** *и. тех.* Текстиль сәнәгатендә өзелгән җепләрнең очларын бәйли торган җайланма. *Заманча төйнәгеч. Автомат төйнәгеч*

**ТӨЙНӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төйнәү**. *Йодрыкка төйнәлгән кулымның авыртмавына аптырап, әле идәнне, әле стенаны төйдем, аннан кинәт кенә кычкырып-кычкырып көлергә тотындым.* А.Әхмәтгалиева

2) *күч.* Күңелгә, йөрәккә авыр йөк булып туплану, җыелу (хис-кичерешләр, тойгылар һ.б.ш. тур.). *Әллә бер-бер төзәлми калган күңел ярасы булдымы, ятим үсkәндә җанына җыелып төйнәлгән рәнҗүе бар идеме – белә алмадым.* Х.Камалов. *Йөрәгенә төйнәлгән җан газабы шулай иртә гүргә кертте дә инде әнисен.* А.Әхмәтгалиева

3) *күч.* Бер төркем булып оешу, берләшү, туплану. *Сугыш чыккан көннән бер урында ике-өч кеше төйнәлсә, якын-тирәдәгеләр иң тәҗел эшләрен дә ташлап төркемгә тартылалар, бергә булырга тырышалар: яхшы хәбәрләр ишетелмиме, сөенечләр колакка кермиме?* А.Гыйләҗев. – *Сезгә сүзем бар, – диде ул, ничектер аеруча тантаналы итеп, – җыелыштан соң берегез дә таралaсы булмагыз, төйнәлеп кенә безгә барыгыз.* Г.Сабитов

4) *күч.* Берәр кая китәргә әйберләрен туплап, әзерләп кую. *Әтисе әнисенә, юлга төйнәлү өчен, дүрт сәгать вакыт бирде.* А.Хәлим

5) *күч.* Оешу, барлыкка килү, формалашу (фикер, уй һ.б. тур.). *Кызда да, Даянда да шундый фикер төйнәлде кебек.* Х.Камалов. *Каләм очына фикер төйнәлде, Яза башлагач, төен чишелде, Сер капчыгым да кинәт тишелде.* Р.Мөхияр

**Төйнәлә башлау** Төйнәлергә тотыну; төйнәлү билгеләре сизелү, күренү. *Газинур кайчан да булса Сәлим белән ныклап бәрелешеп аласын, йөрәгенең ерак-ерак почмагында хәзергә әле сәбәбе дә билгеле булмаган ачу төене төйнәлә башлавын сизә иде сизүен.* Г.Әпсәләмов. *Зәйтүн күңеленнән сурылып чыгып, үзенең җан түрендә йомарланып төйнәлә башлаган куе томан арчылып, ачыклана барган саен, ул түшәккә ныграк сеңде.* Г.Гыйльманов

**Төйнәлеп бару** Рәттән, даими төйнәлү. *Хатыннарның һәр сүзен, ятьмәнең һәр күзен җөпләп, төеннәр төйнәлеп бара.* Ә.Гаффар

**Төйнәлеп бетү** Тәмам төйнәлү, җитәрлек дәрәҗәдә төйнәлү. *Хәлимнең уй очлары төйнәлеп бетүен генә көткән кебек, карт тагын сүз башлады: – Бу китүең белән анаңны рәнҗетмәдеңме соң, олан?* Г.Гыйльманов

**Төйнәлеп калу**Ниндидер бер вакыйгадан, хәлдән соң төйнәлү. *Күңелдәге сораулар бер төенгә төйнәлеп калды...* Н.Гыйматдинова. *Бала күңелендә ачу төйнәлеп калуы бар.* Х.Камалов

**Төйнәлеп кую** Тиз арада, кисәк яки алдан төйнәлү. *Аның, тизрәк Кабан буендагы фатирына кайтып, рәтләрәк киемнәрен киеп, төргәккә төйнәлеп куелган рәсем-сурәтләрен алып, --- туган якларына кайтып китәсе бар иде.* Г.Гыйльманов

**Төйнәлеп тору** Озак вакыт дәвамында төйнәлгән булу; вакытлыча төйнәлгән хәлдә булу. *Карт белән карчык үзләренең күргәннәрен, башларыннан кичкәнне сөйлиләр, эчләрендә 40 ел буе төйнәлеп торган төенне солдатка чишәләр.* Безнең гәҗит

**ТӨЙНӘ́Ү** *ф.* 1) *к.* **төенләү** (*1 мәгъ.*). *Үзе ашыга, кабалана, үзе яулыгын ияге астыннан төйнәргә маташа...* А.Тимергалин. *Көн эссе, егет укытучыларның күбесе башларына кепка кигәннәр, төйни белмәсәләр дә, галстук оештырып куйганнар, аякларында я арзанлы чүәк, я гармун төсле сыдырылган хром итекләр ---.* М.Мәһдиев

2) Төрле вак әйберләрне җәймә, тукыма кисәгенә һ.б.ш. салып, төен хәленә китереп җыйнап бәйләү. *Сепараттан кайтып, ике-өч минут үтте дигәндә, сандыклар актарып, зур бер төенчек төйни дә Көлемсәр келәт артындагы әрекмәнлеккә яшерә.* Ә.Баян. *Гөлтуташ ул көнне дә, иске юрган тышлыгыннан теккән балалар күлмәкләрен төйнәп, һаман да шул үзенең туган авылы Аблайга ризык эзләп чыгып киткән иде.* В.Имамов

3) *сөйл.* Бармакларны уч төбенә кысып йому; йодрыклау. *Төйнәлгән йодрыкларын алга сузган килеш биеп кенә тора.* Ф.Баттал. *Асрау, йодрыгын төйнәп, нидер кычкырып калды.* М.Әмирханов

4) *күч. к.* **җыю** (*21 мәгъ*). *Көтә ана, төйнәп сабырлыгын, Хәбәр китерер, дип, яз ае.* Л.Шагыйрьҗан. *Соңгы егәрен төйнәп, сорарга җөрьәт итте: «Бабай, син соң кем буласың?»* Т.Галиуллин

**Төйнәп алу** Тиз генә, берара, кыска вакытка төйнәү. *Башын иеп, өстәл артыннан кузгалып маташкан Фәһим кире чүкте, әбисе, Рәхимҗан гына күрерлек итеп, йодрык төйнәп алды, Рәшидә, кулларын кушырып торган җиреннән улын кочаклап, тураеп басты.* А.Әхмәтгалиева

**Төйнәп бетерү** Барысын да төйнәү, төйнәүне төгәлләү. *Ниһаять, уйлый башлаган уйларын төйнәп бетереп, Фатыйма карчык сүз башлады: – Фәһимнәрдән һаман хәбәр юк бит әле, карт...* Г.Гыйльманов. *Иртәгесен, иртүк торып, бар мөлкәтен төйнәп бетергәч, яктыга чыгып, Уктау белән хушлашты.* Г.Якупова

**Төйнәп бирү** Башкалар өчен төйнәлү; кем өчендер төйнәү. *Тимерчеумартачының кордашы – аръяктагы Сиражетдин бабай – Актуган кешеләре фикерен бер төенгә төйнәп бирде шикелле.* Б.Камалов

**Төйнәп карау** Төйнәргә тырышу; сынар өчен төйнәү. *Мәнә иртән кызык өчен карандаш юанлыгы кадакны төйнәп карадым.* А.Тимергалин

**Төйнәп кую** Төйнәлгән хәлгә китерү; алдан ук төйнәү. *Ул, кипкән тамагын кырып: – Кызым, миңа хат-фәлән юкмы? – дип, берничә кат эндәшеп карады да, җавап бирүче булмагач, алъяпкычындагы кып-кызыл җиләкләрен яулык почмагына авыштырып төйнәп куйды.* Ф.Яруллин. *Саргылт чәчен баш артына төйнәп куйган, ачык муены мәрмәрдәй ак, шома.* Х.Камалов

**Төйнәп чыгу** Барысын да төйнәү; һәрберсен аерым-аерым төйнәү. *Яулыкларны төйнәп чыкты да кычкырып елап җибәрде.* Мирас

**Төйни башлау** Төйнәргә тотыну. *Төенчегеңне төйни башла: без ике сөйләшмибез.* М.Мәһдиев. *Әйбер-фәләнен төйни башлаганда ук, кайбер дусишләренең, бигрәк тә указга кадәрге өйрәнгәннәрен онытa алмаганнарның, «озату хөрмәтенә бер-ике литр табарсың инде, йоланы бозмыйк» дип кысуларына Александр төкереп тә бирмәде.* С.Шәрипов

**Төйни тору** Берәр эш-хәлгә кадәр төйнәү; аз-азлап, әкренләп төйнәү. *Ул санасын, без кыйссаның Җепләрен төйни торыйк; Ни кылмышын, ни кырмышын, Тормышын сөйли торыйк...* Ш.Галиев. *Можга якларына чыгып кергәнием әле мәнә, түшәк-ястыгыңны төйни тор, дип әйтеп кайттым берсенә.* Р.Гаффар

**ТӨЙТӘ** *и. диал. к.* **түтә** I. *Ә мине, мәнә кара, автомат төйтәсе белән сыйлаганнар иде!* Ш.Маннур. *Мин, бот тиңентен кар ерып кереп, биек кара чыршыга балта төйтәсе белән сугып карадым – таза.* М.Хуҗин

**ТӨК** *и.* 1) Кеше һәм хайван тәнендә үскән йон, чәч бөртеге. *Һаман да нәрсәдер чәйнәгәндәй итеп, төк баскан яңак сөякләрен уйнатып алды да сыңар учы белән яман каты итеп иреннәрен сыпырып сөртте.* М.Хәсәнов. *Тәлгать түләү хакында сүзсез килеште: ат аунаган җирдә төк калмый булмый.* А.Хәлим

2) Мамык, йон һ.б.ш.ларның бөртеге. *Әкрен генә җиргә төшә кар бөртеге. Диярсең каян килгән Бу кадәрле аккош төге?* В.Ильясов

3) Гомумән берәр нәрсәнең бик вак җепселе, бөртеге. *Аш-суга төк төшсә ничек ашарсыз?* Безнең мирас. *Күзгә төк керү*

4) Кайбер тукымаларның кабарып торган йомшак өске катламы. *Бәрхетнең төге кырылган*

◊ **Төкләрен кабарту** Бик нык ачуы килү. *Безнең кунак, почмакка гына посып, тешләрен шыкырдатып, төкләрен кабартып, күзе илә бөтен дөньяны ашамакчы булып утыра иде.* Г.Тукай. **Төк кунмау** Хуҗалык алга китмәү, тормыш рәтләнмәү; мантымау, үсмәү. **Төк куну** Материаль яктан файдасы булу, хуҗалык алга китү. *Бераз акчалары янга калмасмы дип, су санагыч куйдырган булдылар, эшләп баемаганны, моның белән генә төк кунар микән?!* Ватаным Татарстан. **Төк тә төшмәс** Кемгә дә булса һич бернинди зыян килмәс. *Курыкма, андый абыйларың булганда, төк тә төшмәс.* Мәйдан. **Төк чыкмас** Кысыр, баласы булмаган кешеләргә карата әйтелә. *Баласыз вә күсә ир, ягъни төк чыкмас, кысыр кеше.* Р.Батулла. **Төк чыкмау** *к.* **төк кунмау**. *Эшләп, үзләренә төк чыкмауга, төк чыкмау гына түгел,*

*тамак ач, өс ялангач, рәтләп торырлык җылырак, иркенрәк бер куышның булмавына Сәмигулл абзый белән Мәгърифә абыстай бик борчылалар.* М.Гали

**ТӨКӘНМӘС** *с. к.* **бетмәс-төкәнмәс**. *Шулчагында, әйтерсең лә безнең төкәнмәс гәпкә кушылгандай, Чиләбе сәгате тавыш биреп куйды.* А.Тимергалин. *Күңел тулы өмет, йөрәк тулы яра, бу төкәнмәс уйлар кая алып бара?* Э.Шәрифуллина

**ТӨКӘНҮ** *ф.* Бөтенләй бетү, бер дә калмау; ахырына җитү. *Абыем, аеруча хисләнеп китеп, көйгә көй кушыла башласа, сабырлыгым бөтенләй төкәнә.* Р.Рахман. *Тик кошчыкның түземлеге төкәнергә дә өлгерде бугай: нәни канатларын җилпеп очып та китте.* А.Әхмәтгалиева

**Төкәнә бару** Торган саен төкәнүгә якынлашу. *Минем йөрер рәтем көннән-көн төкәнә барганын белми Песнәк!* Г.Тавлин. *Беренче сентябрьнең килеп җитә, җәйге ялның сиздерми генә төкәнә баруы безнең оч малайларының котын ала.* Ф.Яхин

**Төкәнә башлау** Төкәнү алдында тору. *Үзе исә адәм авызыннан моң ишетсә, сабыры төкәнә башлый, күзләре дымлана.* М.Хәбибуллин. *– Синнән җавап көтәм мин, Рухия! – диде Равил, түземе төкәнә башлап.* В.Нуруллин

**Төкәнә язу** Чак кына төкәнми калу. *– Син хезмәткә чытырдап ябышасың да һәммәсен онытасың, безнең күңел гел генә сызып тора, – дигәч, түземе төкәнә язды.* Б.Камалов. *Шундый һәм башка эшкәртүләр нәтиҗәсендә элитасы төкәнә язып, тәмам өне каткан халыкны Хрущёв чорында «җебеткәч», Брежнев заманында сөрсеттеләр.* Р.Зарипов

**Төкәнеп бару** Акрынлап төкәнү, торган саен төкәнү. *Тырышып та барып чыкмый, Төкәнеп бара көчем.* И.Гыйләҗев. *– Ничек киенүе, бизәнүе – аның шәхси эше, – дип бүлдерде гайбәттән түземлеге төкәнеп барган Касыйм Галимович.* Ф.Зариф

**Төкәнеп калу** Ниндидер вакыйга яисә сәбәп аркасында төкәнү. *Нәселдән нәселгә күчеп килгән күрәзәчелек сәләте, Хисбулла вафат булгач, төкәнеп калыр да мәңгегә юкка чыгар микәнни?* Р.Батулла

**Төкәнеп килү** Акрынлап, аз-азлап төкәнү. *Нурисламның да түземе төкәнеп килә иде.* Р.Вәлиев. *– Юк, юк, – диде кыз, үзе дә еш-еш сулап, күрәсең, аның да сабыры төкәнеп килә иде инде, шулай да ул ихтыяр көчен югалтмады.* Р.Кәрами

**Төкәнеп китү** Кинәт төкәнү, көтмәгәндә төкәнү. *Без сезгә генә ышанабыз, хөрмәтле укучылар, шул кытлык беткәнче, сезнең сабырлык төкәнеп китмәсен иде.* Татарстан яшьләре

**ТӨКӘ́Ү** *ф. диал.* Таяк, такта һ.б. кебек ике озын нәрсәне очлары белән бер-берсенә терәү, ялгау. *Таякларны төкәү*

**ТӨКӘШТЕРҮ** *ф. диал.* 1) *йөкл. юн. к.* **төкәшү**

2) Беркетү, тоташтыру. *Чыбыкларны төкәштерү*

3) Бәрелештерү, бер-берсенә тидерү; чәкештерү. *Мин, төкәштерми генә, рюмкадагы коньяк беткәнче эчәм.* З.Зәйнуллин

**ТӨКӘШҮ** *ф. диал.* 1) Бәрелешү

2) *диал.* Сөзешү. *Ике тәкә төкәште. Ике бала бетәште.* Такмак

3) Тоташу, ялгану, кушылу. *Аннан соң, койманың иске өлеше белән яңа өлеше килеп төкәшкән төшләре дә ерактан ук күренеп тора.* Н.Фәттах

**ТӨКЕРЕК** *и.* Авыздагы бизләрдән бүленеп чыга торган сыекча; селәгәй. *Зифа балакай, нәфес җенен басып, төкерек йотып кына утырырга мәҗбүр.* В.Имамов. *– Әллә акыл кергән инде моңа?! – дип, сынык теш арасыннан төкерек атты Мәгъсум.* К.Кәримов

◊ **Төкерегенә дә тормау** *к.* **кисеп ташлаган тырнагына да тормау**. *– Сез аның төкерегенә дә тормыйсыз бит, көнләшеп сөйләп тормагыз инде, – диде ул аптырагач.* Кызыл таң. **Төкерек җиргә төшмәс(лек)** Бик каты, зәһәр (суыклар тур.). *Кышкы көн әнә дигәнче үтеп тә китте, каберне ул көнне ача алмадылар: январь төкерек җиргә төшмәс дәрәҗә суык булып, җир туңы бер метрдан ашу, диделәр.* Х.Сарьян. *Мең тугыз йөз кырык өчнең төкерек җиргә төшмәс суык көннәрендә Сталинград янында шәһид киткән санитарка Нәҗибә бәете Яңавылда кулдан кулга йөрде.* Н.Фәттах. **Төкереккә тайган (нәрсә)** *хурл.* Эш рәтен белми торган, булдыксыз, оешмаган, җебегән кеше турында. *Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә фон өчен генә алынган эпизодик персонажлар еш кабатлана. Фазылҗан абзыйның төкереккә тайган кияве, Әгъләм, Кашшаф – әнә шундыйлар.* Ф.Миңнуллин. **Төкерек кенә** 1) Бик аз; кечкенә, күзгә күренмәслек, сизелмәслек дәрәҗәдә. *Мичкәдәге суны сибеп караган булам: кая ул сүнү, суым ут өчен төкерек кенә.* Н.Хәсәнов. *Көр, чыдам елгыларга әлеге ара төкерек кенә, бер ыргымда калада булачакбыз дип, күңеленә беркетеп куйган иде илче.* М.Әмирханов; 2) Әһәмиятсез әйбер я кеше. **Төкерек йоту** Үзендә булдыра алмаслык, үзе ирешә алмаслык нәрсәгә бик нык кызыгып, көнләшеп карау. *Хәлил төкерек йота, аш урынына таш каба иде түгелме?* Ф.Ярулпин. *Нинди бәхетле кеше ипи ашый икән дип, төкерекләребезне йотып, кызыгып үстек.* Хезмәт даны. **Төкерек чәчрәтү** *к.* **төкерек чәчү**. *Драматурглар утыздан артып китә, дип төкерек чәчрәтәләр, кемне санасаң булмый?* Мәдәни җомга. **Төкерек чәчү** 1) Усаллану, усаллыгын, ачуын белдерү, ярсу. *Кавын баш, Сәет ягына борылып, яңадан төкерек чәчә башлады: – Менәтерәк, күрдеңме инде?* М.Хәсәнов. *Дөрес, төкерек чәчеп тәнкыйтьләүчеләрнең берсе соңыннан хатасын матбугатта таный, әмма бу чакта Андрей Платонович инде исән булмый, дип хәтерлим, төгәл үк истә калмаган.* М.Хуҗин; 2) Буш сүзләр сөйләү, шапырыну. *«Архитекторлар көне-төне шәһәр матур булсын дип тырыша, ә завод безнең таләпләрне искә алмый, бизәк-орнаментларны, архитектура элементларын эшләүдән баш тарта», – дип, җыелыш саен ул төкерек чәчә.* Р.Вәлиев. *Тукта, аның кульъязмасы турында төкерек чәчә түгелме соң?..* Х.Камалов. **Төкерек чәчүче** *кимс.* Үзен белдекле санап, барлык кешедән дә уздырырга тырышып күп сөйләүче кеше, лыгырдык; усалланып,

ярсып сөйләүче. *Чөнки бик батыраеп чәчрәп чыгып форумнарда төкерек чәчүчеләрне күргәч, урамга чыгарга куркып, үткән-сүткәнгә капка астыннан гына өреп калучы дворняжка күз алдына килә.* Безнең гәҗит

**ТӨКЕРЕКЛӘ́Ү** *ф.* Төкерек белән чылату, юешләү. *Наилә шып туктады, күлмәк итәген төкереклә сыпырды, тезе канаган икән, аны төкереклә сыйпаштырды, тамагын кырды ---.* А.Гыйләҗев. *Сипкелле малай ашыкмый гына кулларын төкерекләде, җиңнәрен сызганды һәм, аяк очларына үрелеп, тәмләп кенә Әфләтүневнең маңгаена чиертә башлады ---.* А.Гыймадиев

**Төкерекләп бетерү** Бик нык төкерекләү; күп итеп төкерекләү. *Ул кулларын гына түгел, киемен дә төкерекләп бетерде.* Кызыл таң

**Төкерекләп җибәрү** Бераз төкерекләү. *Ул иң арттан чабып барган Гөлсем янына килеп басты, кулларын төкерекләп җибәрде дә чалгысын янарга тотынды.* Н.Фәттах

**Төкерекләп тору** Һаман, гел төкерекләү, һәрвакыт төкерекләү. *Тагын бер нәрсәне әйтми булмый: Рөстәмнең авызында төкерек күп. Шуңа ул теле белән иреннәрен гел төкерекләп тора.* Ф.Садриев

**Төкерекли башлау** Төкерекләргә тотыну. *Ул, шул сүзне генә көткәндәй, кулларын төкерекли башлады.* Мәйдан

**ТӨКЕРЕКЛӘЧ** *и. зоол.* Күбекле бөҗәкләр семьялыгыннан киң башлы, бик зур булмаган һәм кайберләренең личинкалары төкерексыман сыекча бүлеп чыгара торган бөҗәк; *русчасы:* **слюнявица**. *Тал төкерекләче. Кыр төкерекләче*

**ТӨКЕРЕ́К САВЫТЫ** *и.* Дәвалау урыннарында төкерекне, какырыкны төкерү өчен махсус савыт; *русчасы*: **плевательница**. *Карават янындагы төкерек савытында исә төберчекләр тау булып өелгән.* М.Госманов

**ТӨКЕРЕ́К ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан озынча тар яфраклы, ак чәчәк ата, декоратив гөл буларак та үстерелә торган суганчалы үсемлек; *русчасы:* **птицемлечник**. *Төкерек үләненең кайбер төрләре агулы (аларда гликозидлар булырга мөмкин).* Сөембикә

**ТӨКЕРЕНҮ** *ф.* 1) Еш-еш төкерү. *Юри ачулана башлагач, үпкәли башлагач, тәүбә итәргә, әбиләр кебек, әнисе кебек: «Әйттем исә кайттым», – дип төкеренергә тотына торган иде.* Н.Фәттах. *Минем бәхеткә, ул яшь-җилкенчәкләр, сыйракларын сөйрәп, төкеренеп һәм тәмәкеләрен тарта-тарта чыгып киттеләр.* Ф.Яхин

2) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса кискен ризасызлык, нәфрәт, ачу, җирәнү белдерү. *Форсаты чыккач әйтим инде: сезнең, азгын кәҗә үҗәтлеге белән, җитәкчелекнең теләмәгәнен күрә торып, депутатлыкка ашкынуыгыздан барча намуслы кешеләр төкеренә.* Т.Галиуллин

**Төкеренә башлау** Төкеренергә тотыну. *Килде бугай, кармакны шаярта бугай... тфү... тфү... төкеренә башлыйм.* Г.Ибраһимов. *Гамир, авызында тоз тәме сизеп, төкеренә башлады.* Х.Ширмән

**Төкеренеп алу** Бераз төкеренү; тиз генә төкеренү. *– Дүрәк, ие, – дип, үзүзенә сөйләнеп, төкеренеп алды.* Ф.Җамалетдинова

**Төкеренеп йөрү** Озак вакыт төкеренү; гел, һаман төкеренү. *Косар дәрәҗәгә җиттем, көне буе төкеренеп йөрдем.* Н.Хәсәнов. *Әллә янында һаман өшкеренеп, имләп булашкан Мәймүнә карчыкның төкеренеп йөрүе комачау итте, әллә ул бу зәхмәтле елда ничек еларга кирәген оныткан иде.* Г.Гыйльманов

**Төкеренеп кую** Кисәк, бер мәртәбә төкеренү. *Шунда уйларыннан арынырга теләгәндәй, әчтән генә төкеренеп куйды: «Берүк әйбәт булсын барысы да», – дип, бөтигә янә бармак очларын тигезде.* Ф.Җамалетдинова. *Байталының нинди исемдә икәнен белгәч тә, әбиләр як-якка төкеренеп куйдылар, хатыннар бот чабып көлде.* Р.Зәйдулла

**Төкеренеп тору** Даими, әледән-әле төкеренү. *Казанбаев исә, барына да үпкәләп, бер читтә төкеренеп тордыторды да машинасына утырып китеп барды.* Җ.Рәхимов. *Яисә, кыз кеше тәмәке тартып, сыра эчеп, төкеренеп торганда, аның янындагы тәмәке тартмаган егет, шул кызга карап, нинди хозурлык ала инде?* Мәдәни җомга

**ТӨКЕРТКЕЧ** *и. сөйл. эвф.* Берәр нәрсәне очыртып чыгару, атып җибәрү коралы; автомат. *Рушат, син үзеңнең төкерткечләреңне зур юлга алып чыгасың.* Г.Әпсәләмов

**ТӨКЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **төкерү**. *Кайтырмын, боерган булса, әти канын төкертермен, имансыз булыйм...* Ә.Гаффар. *Менә шул сихерче карчыктан balaңны йоттырып төкертә алсаң, балаң тереләчәк.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Төрле авыруларны, күз тигән кешеләрне яисә бик каты елый торган балаларны махсус догалар укып, төкереп өшкертү. *Бераз өшкертеп, төкертеп караганыгыз юкмы?* Г.Камал

3) *күч. эвф.* Револьвер, пистолет һ.б.ш. шундый ату коралыннан ату. *Мин кергәндә, теге кеше: «Маңгаена берне төкертәсең дә, эһ тә дия алмый», – дип сөйләнә иде бугай.* Т.Гыйззәт. *Мылтыктан ут төкертеп яисә бил алышу юлы белән хәл ителмәсә дә, җиңел көрәш түгел иде бу.* З.Фәтхетдинов

4) Гомумән берәр нәрсәне өрдерү, очыртып чыгару, атып җибәрү. *Автомат әзер макароннарны пакетларга төкертә*

**Төкертә башлау** Төкертергә тотыну. *Шуны гына көткәндәй, безнең өскә ут төкертә башладылар.* Мирас

**Төкертеп алу** Бераз төкертү. *Иң тәүдә хатыныңнан биленә төкертеп ал.* Кызыл таң

**ТӨКЕРҮ** *ф.* 1) Авыздагы селәгәйне тын белән чыгарып ату. *Ниһаять, Таймас уч төпләренә төкерде дә, тирән итеп сулу алгач, багорны тотып, шкафның арткы ягыннан керде.* А.Тимергалин. *– Тәскирә апага әләкләмисеңме соң? – диде Барый, черт итеп җиргә төкереп.* А.Гыймадиев

2) Бәрелү-сугылу, җәрәхәтләнү, авыру һ.б. аркасында авызда барлыкка килгән кан, су һ.б.ш.ларны чыгару. *– Бандитлар! – диде ул һәм авызына тулган ачы канны җиргә төкерде.* Р.Вәлиев. *Ләкин моның бик кыйммәткә төшәсен чамалап, канлы тешләрен гарьлек белән идәнгә төкерде...* Р.Низамиев

3) Авызга капкан азык яки башка нәрсәне кире чыгару. *Ләкин ул авызының тәмсезләнгәнен тойды һәм бу тәмсез сыекчаны шунда ук төкереп ыргытасы килде, ләкин иптәшләреннән яхшысынмады.* Н.Әхмәдиев. *Кыз мондый арзанлы сагызларны күп чәйнәп төкергән бугай.* Т.Галиуллин

4) Дога укып өшкергән вакытта яисә кечкенә балаларга караганнан соң, күз тимәсен дип, төкергән сыман итү. *Әни илне күргәч, аның зурлыгына исе китеп, тирә-ягына бисмилла әйтеп, күз тимәсен дип төкерде.* Г.Исхакый

5) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса ис китмәү, игътибар итмәү, үзе өчен кирәкле дип санамау, санга сукмау, исәпләшмәү, санлашмау. *Мондый гына уңайсызлыкларга төкерә ул.* А.Тимергалин. *Барысына да төкерергә булыр иде, әмма көндәлеге тегә хиснең бурыч дигән нәрсә белән алмашынуы эчне күбрәк пошыра.* Х.Камалов

6) *күч. эвф.* Ату коралыннан пуля, снаряд һ.б.ш.ларны җибәрү; ату. *Юкка гына катыргы мишеньгә тып итеп пуля төкерде.* Г.Рәхим. *Каенише, сүнгән тәмәкесен теле белән әле бер, әле икенче якка күчерә-күчерә, мылтыгын күтәрде, ике көпшә берьюлы ике ут төкерде: кайнар ядрә, кеше йөрәген тишеп, өер башының калак сөяген умырып алып чыгып китте.* Р.Батулла

◊ **Төкерәсем дә килми** Берәр нәрсәгә яки кешегә үзенең тулысынча нәфрәтен, җирәнеп каравын, ризасызлыгын, канәгатьсезлеген белдерә. *Төкерәсем дә килми, әмма мин менә нәрсә әйтергә телим. Бүгенге җитәкчеләр, Аллага шөкер, яхшы эшлиләр, әмма алар тарафыннан телебезнең тамырына балта чабу дигән нәрсә булды.* А.Закирова. **Төкер башына** Артык әһәмият бирмәскә, кайбер нәрсәләргә җиңелчәрәк карарга киңәш итү сүзе. *Һәй, төкер башына... картая башладым, зарланам... илле ел эт типкесендә яшәп тә зарланмаганнарым бүген чыга.* Р.Батулла. *Ташла, төкер башына, ул турыда башыңны ватма.* С.Сабиров. **Төкер дөньясына** *к.* **төкер башына**. *Әй, төкер лә дөньясына. Бер юне чыгар әле.* З.Зәйнуллин. *Сәламәтлек барда Төкер дөньясына... Батма кайгыларга, Катнаш бәйгеләргә ---.* Р.Зарипов. **Төкереп бирү** *к.* **төкереп карау**. *Төкереп бир кемсәләрнең өерелеп өрүенә!* Р.Фәйзуллин. **Төкереп карау** Нәрсәгәдер исе китмәү, кызыксынмау, артык игътибар итмәү, әһәмиятсез, кирәксез дип санау. *Кемнәрдер аны тиргәргә ук тотыналар: «Коллективка төкереп карау бу!»* М.Шабаев. *Гадәттә, хәрби курсларның башына хисе каткан окопниклар әдәбиятыңа, сәнгатеңә, тарихыңа төкереп карый торган наданнарны куя торганнар иде.* Р.Батулла. **Төкереп тә бирмәү** *к.* **төкереп карау**. *Гел элеккечә шыр-мыр, авызы колагында, әллә каян кочакка ташлана, дөньясына төкереп тә бирми.* Ф.Садриев. *Кулыгызда власть булмаса, алар сезгә төкереп тә бирмәсләр иде.* Ф.Баттал. **Төкер танавына** *к.* **төкер башына**. – *Ярар ла, төкер танавына, аның ишеләр өчен борчылып яшәп булмый инде,* – *дип тынычландырмакчы булды аны абыйсы.* Кызыл таң

**Төкерә башлау** Төкерергә тотыну. *Хәл алып, көнбагышның эрерәкләрен генә чамалап, ярып ашый, кабыгын сул тарафына төкерә башлады.* Ф.Яхин

**Төкерә тору** Бернигә дә карамый төкерү; төкерүен дәвам итү. *Аның кем булуына карамастан, аңа төкерә торды.* Х.Ибраһим

**Төкереп алу** Бер тапкыр төкерү; тиз генә төкерү. *Шул арада сул колагы өстеннән чертләтеп төкереп алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ир төкереп алды да борылып өскә менеп китте.* Ф.Җамалетдинова

**Төкереп җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт төкерү. – *Тфү!* – *дип төкереп җибәрде.* Ш.Камал. – *Менә болай!* – *һәм ул шундый озын итеп, шундый еракка төкереп җибәрде ки, без аһ итеп кенә куйдык.* Р.Фәизов

**Төкереп кую** Кинәт төкерү. *Йөкче эндәшмәде, кабина тәрәзәсе аркылы лач итеп төкереп куйды.* А.Гыйләҗев. *Әбүзәр, торып утырып, теш арасыннан гына төкереп куйды.* А.Тимергалин

**Төкереп ташлау** Тиз генә төкерү. *Шул ташны төкереп ташлау нияте белән булса кирәк, ниндидер ямanлык эшләп куюдан да шикләнеп, тышка чыгып китте ул.* С.Поварисов. *Әмма ул каһәр төшкән нәрсә ачы таш булып бугазга утырган: йотып җибәрер идең – артыгын зур, артыгын ачы; төкереп ташлар идең – көч җитми.* Ф.Яруллин

**Төкереп тору** Гел, һәрвакыт төкерү; әле, хәзерге моментта төкерү. *Бу Дилбегә, дөя кебек, минут саен төкереп тора, дип уйлаулары бар, мине хурлыкка калдырма инде...* Р.Нуруллин. *Битеңә төкереп торганда, һаман җиңең белән сөртеп торыргамы?* Ватаным Татарстан

**ТӨКЛӘНҮ** *ф.* 1) Төк белән каплану, төк басу; йонлану. *Аның яңаклары эчкә баткан, төкләнгән ияге алга чыккан, күзләренең дә мае бетеп, элеккеге көлемсәрлеген югалткан.* Х.Камалов

2) Төккә буялу, төк иярү. *Тукыма төкләнү*

**Төкләнә бару** Тагын да күбрәк төкләнү; акрынлап, аз-азлап төкләнү. *Үскән саен төкләнә бара бит алар, бер айдан үзең дә күрерсең.* Сабантуй

**Төкләнә башлау** Төкләнү билгеләре күренү, сизелү. *Кечкенә кош балалары да үсеп җитә башладылар: аларның канатлары ката, үзләре төкләнә башлады.* Ак юл

**Төкләнеп бетү** Тәмам төкләнү, бик нык төкләнү. *Яңакларың төкләнеп беткән ич. Нигә кырып җибәрмисең?* Ш.Камал

**Төкләнеп килү** Акрын-акрын төкләнү, төкләр аз-азлап арта бару. *Көзгегә карады да үз-үзен танымады: төкләнеп килгән бит, каралып беткән күз төпләре, нурсыз күзләр – ничек аңларга соң моны?* Мәйдан

**ТӨКЛӘЧ** *с. сөйл.* Шактый төкле, йонлач; төкләре күп булган, озын төкләр белән капланган. *Атлар арасында бер төкләч, йонлы ат булган икән.* Әкият

**ТӨКЛЕ** I *с.* 1) Төк чыккан, төк баскан; йонлач (кеше тәне, хайван тиресе һ.б.ш.лар тур.). *Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган.* А.Алиш. *Шулай диде ул, карашын кунагының ак күлмәк җиңеннән сузылып чыккан куе кара төкле беләгенә текәп.* М.Маликова

2) Төкләре тырпаеп торган, шома булмаган. *Ләкин күл буеның беренче чәчкәсе – вак киртләч яфраклы, йомшак төкле кычытканның изге ядкәре хөрмәтенә мин аны хәзер дә үземнең бакчамда үстерәм.* Т.Нурмөхәммәтов. *Яфракларның сабакка береккән өлеше – кырыйлары төкле булган көпшәсыман кызгылт үсентеле.* Агулы үсемлекләр

**ТӨКЛЕ** II *с.* 1) Төке кидертелгән; төкеле

2) *күч.* Бәхетле, изге; кадерле, серле, күңел түрендәге, яшерен. *Моңарчы күңелләрендәге уйларын, төкле теләкләрен белдермәүләре дә аны шиккә калдырды.* Ф.Яхин

◊ **Төкле аягы(н) белән** 1) «Йортка, гаиләгә, тормышка бәхет китер, бәхет белән кил» дигән мәгънәдә, гадәттә, кияү йортына яшь килен төшкәндә, кеше беренче мәртәбә килгәндә әйтелә. *– Ходайның бирмеш көнендә бисмиллалы нигезебезгә изге сәгатьтә, төкле аягың белән аяк баса күр, балам, – дип, ике кулын сузып күреште.* А.Хәсәнов. *Бездә, килен төшкәндә дә, төкле аягың белән, диләр бит.* Р.Кәрами; 2) Кемне дә булса шатланып каршы алганда «хуш килдең», «рәхим ит» дигән мәгънәдә сәламләү сүзе. *Солдат кайткан икән, төкле аягың белән, егет.* А.Гыйләҗев. *Төкле аягың белән, түрдән уз, авылдаш!* Н.Фәттах

**ТӨКЛЕ́КАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Тышкы кыяфәтләре белән көя күбәләгенә охшаган, канатлары төк белән капланган, личинкалары һәм курчаклары суда яши торган тулыәверелешле бөҗәкләр отряды; *русчасы:* **ручейники**. *Төклеканатлылар, Антарктидадан кала, барлык континентларда да очрый.* Мәгариф

**ТӨКЛЕКИ** *и. бот.* 1) Ал гөмбәчәләр семьялыгыннан урманнарда, тундрада, сазлыкларда июньнән сентябрьгә кадәр үсә торган кызгылт-көрән төстәге ашарга яраклы гөмбә; *русчасы*: **подорешник**. *Төклеки Көнбатышта деликатес булып санала.* Татарстан яшьләре

2) Бүлбеләре яки сабаклары төк белән капланган үләннәр турында. *Юл буенда үскән төклеки*

**ТӨКЛЕЛЕК** *и.* Төкле булу. *Кулның төклелеге. Яфракның төклелеге*

**ТӨКЛЕТУРА** *и.* Умарта кортлары семьялыгыннан кара өстендә буй-буй сары сызыклары булган төкле гәүдәле элпә канатлы эрерәк бөҗәк; *русчасы:* **шмель**. *Алар, курадан курага очып кунган төклетура кебек, эреләрен генә сайлап җыялар да икенчесен эзләп китәләр.* Л.Ихсанова. *Тракторлар урамның, замана янбакчаларның, агу таратучы сәмәлүтләр бал кортларының, төклетураларның, зәңгәрсу божаннарның башына җиткән.* А.Гыйләҗев

**ТӨКМӘ́-ТӨК** *с. сөйл.* Төп-төгәл. *Ачулануны уен-көлке белән бергә бутап, чын дөреслектә Мөхсиновның канын яхшы ук кыздырып, шулай сөйләшепәрепләшеп торганда (кирәк бит төкмә-төк килергә), урман эченнән, бер кочак яңа суйган юкә төяп, Хаматша дигәне килеп чыкты.* Ф.Хөсни. *Иске чиләк, яңа төк – икесе дә төкмә-төк.* Хезмәт даны

**ТӨКСӘЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **төксәю**. *--- кызның туганнары бернинди әмансәламгә җавап бирмичә, нәсел-нәсәбе кем соң аның, дип, төксәешеп, егетең ятим нәмәстә икән ләбаса, дип, ыржаешып, кызыбызны менә дигән җиргә бирербез әле, дип, кәпәрешеп, ары тайпылып, бире түнеп, бер дә игә килмичә газапладылар.* Ч.Айтматов. *Шулай итеп шул: заманында бөтен Себерне тоткан кунакларыбыз ары талпынып, бире түнеп дигәндәй, ахыр чиктә бернинди дә игә килә алмыйча, төксәешеп, кунарга да калмыйча, төнгә каршы китеп бардылар.* М.Хәсәнов

**ТӨКСӘРТҮ** *ф. диал.* Төксе (*2 мәгъ.*) итү, дорфалату, тупаслату. *Бу рус кызының үзен бер дә зурга куймыйча, тавышын төксәртмәве Фәрхинурда аңа зур хөрмәт тудыра.* Ш.Маннур

**ТӨКСӘРҮ** I *ф. диал.* 1) *к.* **төкселәнү**. *Татлы йокысының төмән җибәрүгә сәбәпче булган яңа күршесенә табигый буларак төксәреп күз төшерде.* Ш.Маннур. *Рәхимҗан төксәрде һәм абына-сөртенә бакчадан чыгып качты.* Н.Гыйматдинова

2) Кызып китеп ачулану. *– Ник минем энем булсын ул?.. – Каян алдыгыз аны?.. – дидем төксәреп.* Ш.Маннур

**ТӨКСӘРҮ** II *ф. диал.* 1) Вак төкләр белән каплану, бала йоны чыгу. *Чык судан, төксәргәнсең!* Ялкын

2) Таушалып искерү, йонлану. *[Корылтай:] Кем булсын, шул инде, тинтәк яшь бикә. Тәмам шиңгән, төксәргән, ак изардай.* К.Тинчурин

**Төксәреп бетү** Тәмам төксәрү, бик нык төксәрү. *Ул шкаф башыннан төксәреп беткән бер дәфтәр алды.* Г.Гали

**ТӨКСӘЮ** *ф. диал. к.* **төкселәнү**. *Әлеге парктагы кебек тәкәбберләрчә төксәюнең эзе дә юк.* М.Госманов

**ТӨКСЕ** *с.* **1.** 1) Кешеләрдә авыр тойгы уята торган, кырыс, караңгы (чырай, кыяфәт тур.). *Алар инде бар нәрсәгә дә битарафлар, күз карашлары ук боздай салкын, төксе, өметсез, хәрәкәтләре җансыз һәм салмак.* А.Тимергалин. *Сәләхетдин, бу сүзләрне ишеткәч, намазыннан туктап, каерылып, малай ягына төксе караш ташлады.* Р.Низамиев

2) Күңелгә авыр тоелырлык, чәнчүле, тупас, дорфа (сүз тур.). *Сугыштан кайткан сәгатендә, капкадан кергәндә ук, ямьсез, төксе сүз әйтте: – Я, син ничегрәк яшәдең мин югында?* М.Мәһдиев. *– Киттек алайса! – дигән булды яшь ир, пассажирының төксе сүзләренә төртелеп калырга теләмичә.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кырыс итеп, усал йөз белән, караңгы чырай белән. – *Әкълимә апа мәктәптә, – дидем мин төксе генә.* М.Маликова. – *Син! – дип төксе итеп дәште ул, өйгә кергәч, Зәмзәмбикәгә: – Син! Син анда гастрольгә китеп...* М.Мәһдиев

2) Тупас, дорфа, күңелгә авыр тоелырлык итеп. *Юан гына бер түти, үтә дә төксе итеп: «Сиңа төшәргә кирәк бит, миңа түгел, шулай булгач, үзең кымшан», – дип җавап кайтарды.* Ф.Җамалетдинова. *Әниең исән булса, син аның белән болай төксе сөйләшмәс идең.* Г.Тарханова

**ТӨКСЕЛ** *с.* 1) Төкләре булган; төк үскән. *Трофобласт үсешен тикшергәндә, нормаль йөклелек очрагында, трофобласт элементларының соңгылыкның төксел араларыннан ана организмына күчеп йөрүе (миграциясе) кызыксыну уята.* Фән һәм тел

2) Йонлач, мамыклы, йонлы. *Купчелек яшьтәшләре кебек, ул да Тимерьюлчылар сараена биюләргә яңа габардин кытай костюмы, ефәк күлмәк, очлы башлы лакланган штиблетлар, каракүл шәл якалы төксел йон тукыма – ратин пәлтә киеп килү турында хыяллана --- иде.* Р.Мирхәйдәров

3) *сөйл. к.* **төксе**. *Аның тар соргылт күлмәге төксел чыраена тәңгәл килеп тора иде.* З.Хәким

**ТӨКСЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Төксегә әйләнү, кырыслану, ачуын йөзенә чыгару, йөзе караңгылану. *Шуңа күрә аз сүзле Котлый тагын да төкселәнде, бөтенләй дәшмәс булды.* Р.Батулла. *Хәтирәнең күз карашлары очкынланды, ул хат авторын күрергә тырышкандай төкселәнде, йөзенә үч алу, усаллык хисләре ташып чыкты.* Н.Хәсәнов

2) *күч.* Караңгылану, ямьсезләнү, матурлыгын югалту. *Көн кинәт төкселәнде, шул хәл аны уйларыннан бүлде, һәм ул кояшка күтәрелеп карады.* М.Хуҗин. *Ләкин 1861 елның апрелендә табигатьнең гомер-гомердән килгән бу гармониясе, күңелне җилкендерүчән шатлыгы җан тетрәткеч хәбәрдән төкселәнгәндәй, бозылгандай булды.* Р.Сабиров

**Төкселәнә бару** Торган саен төкселәнү. *Сорау биргән саен аның чырае караңгылана, төкселәнә барды.* Татар әдипләре

**Төкселәнә башлау** Төкселәнү билгеләре күренү. *Йөзе төкселәнә башлаганны күрмәмешкә салыштым ---.* Р.Вәлиева

**Төкселәнә төшү** Бераз төкселәнү; тагын да төкселәнү. *--- әмма ул моның белән генә дә калмады, шундук җитдиләнеп, хәтта ничектер төкселәнә төшеп өстәде: – Бөтен рәтле ир-ат фронтта, без генә монда сузылып йөри алмабыз.* Ф.Хөсни

**Төкселәнеп бетү** Бик нык, тәмам төкселәнү. *Бу керләнгән дөньяда яшәп төкселәнеп беткән кешеләрнең, гөнаһсыз, пакь күңелле сабыйлар күргәндә, күзләре яктырып китүе җир йөзендә шәфкать һәм мәрхәмәтнең әле исән икәнлеген исбатлый кебек юкса...* Татарстан яшьләре

**Төкселәнеп китү** Нindидер вакыйгадан, сәбәптән соң төкселәнү. *Бу сүзләрдән Габделбәр, янтыгына очлы без кадагандай рәвештә йөзен яман чытып, төкселәнеп китте ---.* Э.Касыймов. *Әллә ничә кеше артыннан кунакка чакырып җибәргән Сибгатулла үзенең элекке күршесенең ни йомыш белән йөрүен ишетүгә үк төкселәнеп китте.* Ф.Яруллин

**Төкселәнеп тору** Әле, сөйләү моментында төксе булу; даими, һәрвакыт, гел төкселәнү. *Гайфулла, Тәнзиләнең төкселәнеп торуын яратмыйча, хуҗалар сизмәслек кенә итеп күз кысып алды.* А.Гыйләҗев. *Эшебез авыр дип төкселәнеп тормадылар.* Якты юл

**ТӨКСЕЛЕК** *и.* Төксе булу сыйфаты, хәле. *Ул нык бирешкән, йөзендәге элеккеге шәфкать нуры юк инде, аны кайгы һәм төкселек пәрәвезе япкан шикелле.* Х.Камалов. *– Безнең хәлләрне бик беләсең килсә, үзең авылга кайтып бел, – диде Һиражҗ, тавышына төкселек чыгарырга тырышып.* Н.Акмал

**ТӨКСЕЛЛЕК** *и.* Төксел булу. *Тукыманың төкселлеге*

**ТӨКСЕМ** *и.* 1) Нечкә, кыска төк; төкчә, йонча. *Бластоциста трофобластлары, эндометрия тукымаларына чумып, митоз (күзәнәкләр бүленү механизмы) юлы белән үсеп китә, күпкатлаулыга әверелә һәм беренчел төксемнәр хасил итә.* Фән һәм тел

2) *сөйл. к.* **төксе**. *– Улым, мөселман кешегә бер дә муафикъ түгел бит әле болай төксем булып йөрү, – диде беркөн әтисе.* С.Поварисов

**ТӨ́К-ТӨК** *ы.* Тәкәне, үгез бозауны сөздергәндә әйтелә. *Аннары идәнгә сикереп төшә дә, мич казнасы буенда рәхәт кенә күшәп яткан ике бәрәнне кузгатып, төк-төк-төк дип, уч төбен сөздерергә маташа башлый.* Ш.Маннур

**ТӨКҮ** *ф.* 1) Нindидер авыр әйбер белән этү, этәрү

2) *диал. к.* **сөзү**. *Сыер төки Җәгъфәрне.* Н.Исәнбәт. *Алда кулына пистолет тоткан таза гәүдәле (офицер булгандыр, дидем) үз солдатларына тидерүдән куркыптырмы, яисә минем ычкына алмавыма ышаныпмыдыр, атмыйча басып карап тора иде, анысын да баш белән төкеп очырдым да, тор да йөгер.* М.Имамов

**ТӨКЧӘ** *и.* 1) Нәзек, кыска төк. *Каш төпләреннән тырпаеп килеп чыгарга гына торган тупас төкчәләр дә элекке кебек авырттырып йолкынмый.* Р.Рахман. *Йомшак кагыну каурыйлары төкчәләр белән капланган, бу исә аңа тавышсыз очарга мөмкинлек бирә.* Биология

2) *бот.* Үсемлек тышчасында жепсел үсенте. *Чистартканнан соң, җимешләрне бер мәртәбә суда чайкатып алыгыз: бу – аның эчендәге төкчәләре калмасын өчен эшләнә.* Безнең гәҗит. *Кычытканның чагу үзлеге төкчәләрнең тукыма согындагы кырмыска кислотасыннан.* Мәйдан

3) Кеше һәм хайван организмында кайбер органнарның эчке тышчаларындагы микроскопик үсентеләр. *Эчәк төкчәләре*

4) *зоол.* Түбән төзелешле организмнарның хәрәкәтләнү органнары; камчы

**ТӨКЧӘЛЕЛӘР** *и. күпл. бот.* Сабаклары һәм җимешләре бик вак төкчәләр белән капланган икеөлешле үлән үсемлекләр семьялыгы; кычу үләннәре; *русчасы:* **ворсянковые**. *Төкчәлеләр Көнчыгыш һәм Көнбатыш Азиядә, Урта диңгез буенда күп үсә.* Биология

**ТӨЛЕРҮ** *ф. иск.* Йокымсырау, черем итү. *Аз гына төлерү*

**ТӨЛКЕ** *и.* **1.** 1) Этләр семьялыгыннан җирән йонлы, озынча борынлы, кабарып торган озын койрыклы ерткыч хайван. *Юлдан аерылып, урман эченә кереп киткән сукмак аланчыгында елгыр төлке уйнаклый иде.* Р.Батулла. *Инде барып җиттем дигәндә, әлеге төлке бер кукәйне эләктереп шылды.* Г.Якупова

2) Шул хайванның тиресе, күреге. *Аңа ул тар билле, озын итәкле сарык туны, кара төлкедән теккән шәп бүрек вәгъдә итә.* Ә.Еники. *Ул төлкеләрне күптән тегүчегә илтеп бирдем инде мин.* Мәйдан

3) *күч.* Бик хәйләкәр, мәкерле, астыртын эш йөртүче кеше. *Исхакка бераз таныш кебек күренгән егет, аның янына килеп: – Дөрес сукалый бу төлке! – диде.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Шул хайван күрегеннән тегелгән. *Төлке яка. Төлке тун*

◊ **Төлке мае сөртү** Хәйләләү, алдау. *Аларда да шомалар, башкаларга төлке мае сөртергә әзерләр җитәрлек.* Н.Шәфигуллин. **Төлкене көлкегә калдырырлык** Бик хәйләкәр, алдакчы кеше турында. *Хәйлә дигәндә, төлкене көлкегә калдырырлык сәләтем бар.* Д.Аппакова. **Төлкенең өстенә барып чыга торган** Бик буранлы (көн тур.). **Төлкене үз мае белән майлау** 1) Килгән кунакны үз кучтәнәчләре белән сыйлау; 2) Хәйләкәр кешене алдау. **Төлке тиресе ябыну** Хәйләкәрләнү, хәйлә белән эш итү, алдау, астыртын эш итү. *Төлке тиресе ябынганнардан сак бул: Башактан икмәккәчә юл – бик озак юл.* Ә.Синугыл. *Күз белән күрмәгән көчкә табынма, Өстеңә төлке тиресе ябынма.* Р.Ханнанов. **Төлке шулпасы эчү** *к.* **төлке мае сөртү**. *Алдаганнар сезне! Алдау-хәйләләүне «төлке шулпасы эчү» дип атыйлар...* Р.Сибат. *Аның төлке шулпасы эчәргә маташуын яшь бүлмәдәше Фәүҗәт шундук сизеп алды, егетнең тумбочкасына ишарәләп: – Акчаң булмаса, әнә кичә алып кайткан транзисторыңны бир, – диде.* Р.Кәрами

**ТӨЛКЕ́ КОЙРЫГЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан уҗым арасында үсә торган туры сабаклы, эре һәм таралган себеркәчтә вак башакчыклары урнашкан чук чәчәкле чүп үләне; *русчасы:* **метлица обыкновенная**. --- *аяк астымдагы кайчандыр трактор ярган ызан, чокыр-чакыр, тәртипсез киселгән агач төпсәләре, ботак-санак, чытырман алга барырга бирми, чабылмый калып, урман кебек үрчегән кыргый үлән, кырлы курай, төлке койрыгы һәм башка шырлык аякка урала.* А.Хәлим. *Аның безгә халык телендә чыпчык тарысы, төлке койрыгы, әтәч кикриге, хәтфә гөл дип йөртелә торган, чүп үләне саналган кыргый сортлары гына билгеле.* Безнең гәҗит

**ТӨЛКЕКОЙРЫК** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан озын сабаклы, озынча чук чәчәкле һәм кыйммәтле терлек азыгы булган үлән үсемлек; *русчасы:* **лисохвост**. *Болында тукранбашлар, тычкан борчагы, кырлы борчак, казаяк, олыбаш, кындырак, төлкекойрык һ.б. болын кыяклылары үсә.* Татарстан географиясе

**ТӨЛКЕЛӘНҮ** *ф.* Хәйләкәрләнү, хәйлә кору. *Төлкеләнә белү хирыслыгы Шашкинның үзендә дә мең вагон.* С.Поварисов. *Алай алдашуны, төлкеләнүне яратмый да, булдыра да алмый иде ул.* Ф.Садриев

**ТӨЛКЕЛЕК** *и.* 1) Хәйләкәрлек, астыртынлык, елгырлык, алдакчылык. *Ә Салисәдә дипломатлык, төлкелек һәм мәкерлек поты белән иде.* М.Шаһимәрдән. *Кемдә попугайлык көчле, кемдә төлкелек, сарыклык, куянлык, еланлык, ишәклек, бөркетлек...* Р.Зарипов

2) Хәйләле эш-гамәл; астыртын кыланыш. *Мине дә, мөсафирны күрер өчен, үз бүлмәләренә һич җибәрмидер. Бу төлкелек түгелме?* М.Акъегет. *Әсәрләре белән ни гомер файдаланган бер мөхәррирне атналык тормышын да тәэмин итмәслек бер хак белән эксплуатацияләргә теләү, аның аптыраулыгыннан файдаланып, хиссиятен мыскыл итү төлкелек түгел дисезме?* Р.Шәрәфиев

**ТӨЛКЕЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Хәйләләү, алдау, алдашу; астыртын гамәлләр кылу. *Миңа карата төлкелек итә башлады.* М.Акъегет

**ТӨЛКЕТАМАК** *и.* **1.** Төлкенең тамак турысындагы мехыннан тегелгән тун я башка кием. *Кияләр төлкетамак, Җиккәннәре – аргамак ---.* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән, әзерләнгән (яка, тун һ.б.ш.). *Болар эчендә үзенең зур буе, мөмтаз кыяфәте белән иң элек Җәләл мулла күзгә чалына: аның башында яңа камалы бүрек, өстендә зур якалы, яхшы тышлы төлкетамак толып, аягында шәһәр эше яхшы калуш пима.* Г.Ибраһимов

**ТӨЛКЕ-ТӨЛӘЙМАН** *и.* 1) Әкият персонажы буларак төлке. *Кемдә йөзек, диләр, шул Сөләйман, Ул Сөләйман – төлке-төләйман!* Х.Мәхмүтов. *«Төлке, төлке-төләйман, төнлә кая барасың?» «Әбиләргә барамын!» – дип такмаклый торганнар иде бала-чагалар.* Р.Батулла

2) *күч.* Бик хәйләкәр, астыртын, алдакчы кеше. *Төлке-төләйман икәнлеген әллә кайчан белә идем дә бит ---.* Р.Вәлиева

**ТӨЛКЕЧЕ** *и.* Төлке аулаучы, төлке аулау белән шөгыльләнүче. *Малайның йөзе яктырып китте: – Әһә, шулай булыр ул Күктау мәргәне, төлкече Мифтах малае!* А.Гыйләҗев. *Яки, шаяруга күчеп, «Минем әти төлкече, төлке аулап йөрүче»не сыздыра.* Х.Камалов

**ТӨМӘН** I *сан.* **1.** *бор.* Ун мең. *Бернең бәласе меңгә, меңнең бәласе төмәнгә.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Бик күп, хисапсыз күп. *Изге җаны авырлыксыз күккә ашсын, Атабыз катына барып ирешсен, төмән еллар, йолдыз булып, адашканнарга юл күрсәтеп балкып торсын, диде.* Н.Фәттах

**3.** *и. мәгъ.* 1) *тар.* Ун мең кешелек гаскәр берәмлеге. *Кырык меңлек дүрт төмән куркыныч сәфәргә юнәлде.* Р.Сәгъди. *Бу егерме төмәннең күбесе Идел буенда утырып кала.* Х.Миңнегулов

2) *тар.* Ун мең кешелек гаскәр туплаpлык өлкә. *Бер яктан, янәшәсендә Плано Карпини әйткән бөек хан төмәннәре (биләмәләре) торуы моны аның өчен котылгысыз бер нәрсәгә әйләндергән.* Мәңге тонықланмас көзгебез

3) *тар.* Шул өлкәнең үзәге булган шәһәр

4) *к.* **төмәнбашы**. --- *билгеле ки, алар борын-борыннан хәрби хезмәт кешеләре булганнар, Алтын Урда заманында мең башы, ун мең башы булып торганнар, ә татарлар гаскәр башында торучыны кайчандыр «төмән» дип атаганнар.* Ә.Еники. *[Чөнгут:] Төшендем, бөек төмән.* Г.Каюмов

◊ **Төмән төрле** Бик күп; исәбе-саны билгесез. *Төмән төрле хан күрдем, Берсен хан дип белмәдем.* Дастан. *Боерыгыз гына – барам үзем мин, Чакыртып яныма, әйтәм сүземне, Төмән төрле сөйләп җанлы телемдин, Эшкә җигеп акыл белән белемне.* Й.Баласагуни

**ТӨМӘН** II *и.* 1) XVIII гасырда Төмән (рус. Темников) шәһәреннән башлыча Көньяк Урал төбәкләренә күчеп килгән мишәрләрнең бер төркеме. *Дөрес, килеп чыгышлары белән алар татар-мишәрләр, моны берсе дә инкяр итми, ә шулай да үзләрен ни өчендер «төмән» дип атарга гадәтләнгәннәр.*

Ә.Еники. *«Мишәр» үзатамасы бик киң таралган, ләкин бердәнбер булмаган: еш кына татар, алатыр татары һәм төмән этнонимнары очрый.* Татарлар – халык исәбен алу һәм сәясәт

2) Башлыча Төмән шәһәре тирәсендә яшәүче себер татарлары төркеме. *Бу лексик берәмлек төмән, тубыл сөйләшләрендә ‘комагай, туймас күз’ мәгънәсендә очрый.* Ф.Хисамова

**ТӨМӘ́НБАШЫ** *и. тар.* Ун мең кешелек гаскәр башлыгы. *Аның бит элекке төмәнбашы Куям зур чирү белән Болгарда калган.* И.Хуҗин. *Башта ук шуны әйтергә кирәк: Мамай морза беркайчан да Алтын Урда тәхетендә хан булмаган, ул Чыңгыз нәселеннән түгел, ә Бирдебәк ханның кияве, төмән башы.* Ф.Бәйрәмова

**ТӨМӘ́НБӘГЕ** *и. тар. к.* **төмәнбашы**. *Һәр өлкә башлыгы кытайча «вань-ци», русча «темник» дип атала. Татарча бу «төмән» яисә «төмән бәге» дигәнгә туры килә.* Н.Фәттах

**ТӨМРӘЕП** *рәв.* Тулы булып, таза булып, томрап

**ТӨМРӘЕШҮ** *ф. диал. урт. юн. к.* **төмрәю**. *Балалар, төмрәешеп, ишеккә төбәлделәр.* А.Расих

**ТӨМРӘЮ** *ф. диал. к.* **томсаю**. *Төмрәю бер дә килешми инде сиңа.* Мирас

**Төмрәеп тору** Һәрвакыт, гел төмрәю; төмрәйгән хәлдә булу. *Гыйззәтулланың төмрәеп торган тулы матур бите ертылып китте.* А.Расих. *Төмрәеп торган сөекле газиз хатыныңны кая куярсың?!* Ж.Дәрзаман

**Төмрәя бирү** Бернигә карамый төмрәю. *Арбалар өстенә бөркәнчекләр ябынып, төмрәя биреп утырган хатыннары белән янәшәләп, башкортлар да агыла башлады.* Безнең юл

**ТӨМСӘ** *с.* **1.** 1) Тоныкь, сүрән (ут, яктылык һ.б.ш. тур.). *Ерак-еракларда чит промыслоларда яндырылган шундый ук факелларның төмсә һәм юаш утлары, караңгы диңгез буйлап, су өстеннән күңелгә ягымлы йомшак нур сызыклары җибәреп торалар.* Ш.Камал

2) Караңгы, болытлы. *Үзәккә үтә Чамасыз яңгырлары. Төмсә күккә карый-карый, Малай күп каңгырады.* Р.Зәйдулла. *Кирегә юл юклыгын хатын яхшы аңлый, шуңа, апасы авылга кайткан төмсә көнне каһәрли-каһәрли, һаман кер уа бирде...* Ф.Җамалетдинова

3) *күч.* Караңгы чырайлы, ягымсыз, тупас. *Төмсә генә чырайлы хуҗабикә (илле биш яшьләрдә булыр) ишегалдында безне сорау белән каршы алды: «Сез язучылармы, артистлар буласызмы?»* М.Галиев. *Сафринәнең әбисе күршекүлән белән дә аралашмаган төмсә карчык иде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тоныкь кына. *Фонарь утлары вак яңгыр арасында йолдызлар кебек төмсә генә ялтырашып күренәләр.* Ш.Камал

2) Караңгы чырай белән, теләртеләмәс, тупас итеп. *– Начар түгел, – диде Иргәш төмсә генә.* Т.Әйди

**ТӨМСӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Төмсә булып китү, тоныклану, караңгылану. *Колхозның көтүе җәйләүгә кайтып кергәндә, көн төмсәләнеп өлгергән иде инде.* Р.Мөхәммәтҗан. *Кыйгачлап төшкән кояш нурларында ул, көмеш тәңкәләрен җемелдәтеп, гүя чалкан ята, ике як ярдан аңа елак тирәкләр иелгән, офыкка табарак карагачлар төмсәләнеп күренә, дөньяның киңлеген, дәһшәтен бөтен күзәнәкләрең белән тоясың: бирегә син бик бәләкәй икән!* Р.Зәйдулла

2) *к.* **төкселәнү**. *Бераз шулай әвәләгәч, Тынчурин ботка төерен авызыннан кашыгына чыгарды һәм, төмсәләнеп, савытка куйды.* Г.Үзиле

**Төмсәләнеп калу** Нинди дер сәбәп, вакыйга, сүз, уй һ.б.ш.лардан төмсәләнү. *Бар дөньясын онытып, шаярыпкөлеп утырганда, кинәт уйга чума, күз карашы төмсәләнеп кала.* С.Сабиров. *Ул карашны тымызык көзге көннәрдә җанны кысып җиргә иелгән болытлы күк йөзеннән дә, таң беленеп килгән тәрәзәдән дә, төмсәләнеп калган су өстеннән дә күреп сискәнеп китә иде Өлкән Сәгыйрь.* М.Галиев

**ТӨМСӘРҮ** *ф. диал. к.* **төкселәнү**

**ТӨН** *и.* 1) Тәүлекнең кояш батышыннан кояш чыгышына, ягъни кичтән таңга кадәрге өлеше. *Ашыгам, Хәтимә, төн булганчы Казилегә кайтып җитәргә кирәк.* И.Юзеев. *Эштән тәмам бетеп, төн уртасында кайтып егыласың, иртән, күзне тырныйтырный ачып, тагы эшкә чыгып чабасың.* Х.Камалов

2) *иск. к.* **төньяк**. *Аның бер башы төшлеккә, бер башы төнгә карыйдыр.* К.Насыйри

◊ **Төне якты, аты яхшы** Уйлаган ниятне тормышка ашыруда бернинди куркыныч юклыгын белдереп кулланыла. *Төне якты, аты яхшы, дигәндәй, әйдә, ул турыда кайгырып баш ватмыйк әле, яхшы кеше ялгыз булмый ул.* Г.Бәширов. **Төн йокысы качу** *к.* **йокы качу**. *Кайчагында әтисенең сүзләре аны шулкадәр мавыктыра: Ишниязның күзеннән төн йокысы кача ---.* Г.Әпсәләмов. *Рифкать дәреслекләренә аның саен үҗәтләнебрәк тотынды, төн йокылары качты, урамга да чыкмады, ябыгып, суырылып калды.* Р.Вәлиев. **Төн йокысы күрмәү** Бөтенләй йоклый алмау. *Энкече ирнең хатыны да, анасы да төн йокысы күрми.* М.Кәбиров. **Төн йокысы күрсәтмәү** Төнлә йокларга бирмәү. *Элегрәк үзе ише күзләре калайланган бәндәләр җыеп, төн йокысы күрсәтми иде.* Кызыл таң. **Төн йокысын калдыру** Төнне йокламыйча үткәрү; төн йокысы исәбенә нидер эшләү. *Егет йөри маллар өчен төн йокысын калдырып.* Г.Рәхим. *Бу оекларны әни төн йокыларын калдырып бәйләде.* Л.Лерон. **Төн йокысын качыру** Хәвефле эш яки психик халәт аркасында кемгә дә булса йокларга бирмәү. *Җил көчәйде, кузгатырга мөмкин булган бар нәрсәләргә кагылып, аһылдап, төн йокысын качырып туктаусыз усалланды.* А.Гыйләҗев. *Күпме кешенең төн йокысын качырган да бу адәм, төне буе үзен эзләп йөрергә мәҗбүр иткән дә, бер тәүлеккә якын вакыт узгачтын гына, кеше күпме изалангач кына, ниһаять, акылына килгән ул!* М.Вәлиев. **Төнне көнгә, көнне төнгә катып** *к.* **төнне көнгә, көнне төнгә ялгап**. *Төнне көнгә, көнне төнгә катып, бөтен тирә-якны айкадылар.* Г.Ибраһимов. **Төнне көнгә, көнне төнгә ялгап** Көн-төн, көне-төне (эшләү, көтү һ.б.ш. тур.). *Сугыш беткәч тә, тыл каһарманнарының төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләүләре турында сөйләү авылыбыз үзешчәннә-*

*ренең патриотик җырлары белән үреләп барды.* Х.Сибгатова

**ТӨНӘ** *рәв. диал.* **1.** Кичә. *Киткән төнә әбиең урманга, имән себеркесенә.* Н.Гыйматдинова. *Шәп алышканнар төнә!* Р. Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ.* Кичәге, үткән. *Актыр минем беләгем, сабынладым төнәген, Төнә көнге егет өчен һаман яна йөрәгем.* Җыр

**ТӨНӘГЕ** *с. диал.* Кичәге, үткән көндәге. *Төнәге сүзне бүген дә кабатлау*

**ТӨНӘ́ГЕН** *рәв. диал.* Кичәге, үткән көнне. *Төнәген генә тап-таза йөргән кеше бүген үле-мәле ятсын әле.* А.Гыйләҗев. *Төнәген Юмаевка биргән сорау галәмәтедер инде бу.* В.Нуриев

**ТӨНӘ́ГЕНӘК** *рәв. диал.* Кичә, үткән көнне. *Төнәгенәк Пытыр Әйшәнең аягыннан ярты литр бозык канын суырттырдым.* Н.Гыйматдинова

**ТӨНӘК** *и. диал.* 1) Торак, яшәү урыны; өй, йорт. *Төнәргә төнәге булмаган кешегә кыз бирмиләр.* Мәкаль

2) Вакытлыча тукталу, яшәү урыны. *Ялгышканга җәза Тәңре кулында; Төнәк кенә безнең юлда бу дөнья.* Й.Баласагуни

3) Тавыклар кунып, төн уздыра торган урын; куна́ча

**ТӨНӘКЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Төнгегә кунаклау. *Тавыклар төнәкләгәнне көтү*

2) Куну, төн үткәрү. *Тәүдә малайның уе хәзер үтеләчәк Күлләр авылында төнәкләп чыгарга иде.* А.Хәлим

**ТӨНӘ́-КУНА** *рәв. сөйл. к.* **куна-төнә**. *Мондагылар белән эшен бетергәч, санитария фельдшеры, үзләренең машинасына утырып, басуга, төнә-куна ятып эшләүчеләр янына китте.* Н.Фәттах

**ТӨНӘРТҮ** *ф.* 1) Изрәтү, йомшарту

2) *к.* **төнәтү** (*4 мәгъ.*). *Агачлар куелыгыннан чыгуга, биткә мең төрле чәчәкләр белән төнәртелгән җылы һәм коры алан һавасы килеп бәрелде.* Г.Бәширов. *1 аш кашыгы кара тмин орлыгын 1,5 стакан суга салып, 5–7 минут кайнатырга, 10 минут төнәртергә, сөзәргә.* Мәйдан

**ТӨНӘРҮ** *ф. диал.* Оюю, изрәп йоклап китү, түнү. *Йокыга гына төнәрәсең, мәче кебек куенга керергә генә торалар.* Д.Салихов

**Төнәреп алу** Аз гына төнәрү, кыска вакытка төнәрү. *Мин дә, өйгә кайтып, ике-өч сәгать кенә төнәреп алырмын да, таң атыр-атмас килеп тә җитәрмен, Рифат абый.* Р.Фәизов

**ТӨНӘТМӘ** *и.* Җиләк-җимеш, төрле үләннәр салып, суда, спиртта төнәтелгән сыеклык. *Әллә нигә тапкыр сөт җылытты, үләннәрдән төнәтмә ясап эчертте.* С.Зыялы. – *Ханның аякларын шушы төнәтмә белән юарсың, – диде ул төксе генә.* М.Әмирханов

**ТӨНӘТҮ** *ф.* 1) Суга яисә спиртка җиләк-җимеш, дару үләннәре һ.б.ш.ларны салып эчемлек әзерләү, төнәтмә ясау. *Ылысларны төнәтү юлы белән елның теләгән бер фасылында витаминлы-шифалы эчемлек алып була.* Р.Әхмәтьянов. *Тәмәке тартмый, эчкәндә дә, мүк җиләгеннән үзе төнәтеп ясаган куе шәрабны бер касә генә тотып куя...* Р.Зәйдулла // Шундый сыеклыкның әзер булуын көтеп, билгеле вакыт тоту, саклау. *Бу очракта 10 л суга 100 гр известь кушып, 4 сәгать төнәтергә кирәк.* Мәйдан

2) Төрле үләннәр, җиләк-җимешләр кушып, чәй пешерү. *Хуҗәбикә әллә нинди сихри үләннәр кушып төнәтелгән яшел чәй ясап өлгерткән иде, кунак кыяр-кыймас кына урындыкка барып утырды.* Ф.Бәллүр. *Хезмәттәш дусты Галим аны, гадәтенчә, хуш исле яфраклар салып төнәтелгән татлы чәе, бал-шикәре, тәм-томы белән сыйлады.* Ф.Яхин // Нәрсәне дә булса кайнар суда тоту яисә бераз кайнатып алу. *Кычыткан суында төнәтелгәнгә бинт яшел була икән.* Х.Камалов

3) Әле генә үлгән мәет янында төн уздыру, аны саклап төн чыгу. *Ни, син хәзер ук төнәтергә карчыклар чакыр. Коръән чыгарга мулланы алып кил.* Р.Уразголов

4) *сир.* Йокламыйча уздыру, үткәрү (төнне). *Әй озын төннәр төнәткән, Җепләр эрләгән матур. Бозлы тәрәзәдән карап, Яшьләр күзләгән матур!* Ә.Сәгыйди

5) *иск.* Кемне дә булса алдау

6) Берәр нәрсәнең исен һавага яки башка нәрсәгә тарату, сеңдерү, төтәсләү, кушу. *Төнге дым һәм черегән яфрак исе белән төнәтелгән салкынча һава тәнгә үтеп керә башлаган иде.* З.Фәтхетдинов. *Карчык аның берни сизмичә, үлем йокысы белән йоклавын көтте, Асылгәрәй картның борын төбендә үзенең үлән-тамырларын төнәтте, һава алыштырды.* Ф.Бәйрәмова // Күчерү, алдыру, бирү. *Шунда Кояш, май коңгызын сак кына учына алып, аңардан үз толымнарына ут төнәтеп җибәргән дә, балкый-балкый, кабат Күккә менеп киткән.* Г.Гыйльманов

7) *күч.* Кемне дә булса интектерү, тинтерәтү, азаплау (гадәттә көттереп); кыенлык тудыру. *Гераздән кенәз булганны күптән бер төнәтергә кирәк иде инде.* М.Хәсәнов. *«Тагын нәрсә уйлап чыгардылар икән? Әллә, Харитоновка буйсынмаган өчен, мине төнәтергә уйлыйлар микән?» – дип фикер йөртте Борһанов.* Г.Ахунов

8) *күч.* Кемгә дә булса үзе кылган берәр эшнең начар, зарарлы булуын аңлату, аны бүтән кабатламаслык иттерү. *Ул тол хатын Хәнифәнең өй эчендәге чүпне тышка чыгарганлыгына гаять дәрәҗәдә ачуы килеп, туктале, мин аны төнәтим әле, дигән уйны күңелендә асрый башлады.* Г.Ахунов. *Милләтең исемен оныт, дип, мең кабат төнәтелгән!* Р.Әхмәтҗан

**Төнәтеп алу** Тиз генә төнәтү; аз гына төнәтү. *Эчәклекләре белән кыенлыклар туган һәм эч сыекланудан интеккәннәр бер аш кашыгы киптерелгән бакча җиләге яфрагын бер стакан суга салып, 30 минут төнәтеп алсын.* Безнең гәҗит

**Төнәтеп кую** Төнәтелгән хәлгә китерү; алдан төнәтү. *Төнәтеп куелган үлән чәен генә эчте ул.* Кызыл таң

**Төнәтеп тору** Әле, хәзер төнәтү; гел, һәрвакыт, еш төнәтү

**ТӨНӘ́Ү** *ф.*1) Төн уздыру, төн куну. *Бу гөрелте вокзалның өченче класс залында таш идәнгә ятып төнәгән юлчыларны да сискәндереп уята.* К.Нәҗми. *Төн төнәгән саен якты янып, үзенә чакыра синең хисеңне.* Ш.Маннур // Йоклап алу, черем итү. *Ул аз гына төнәгән булган икән*

2) *сөйл.* Нинди дә булса эшнең, гамәлнең авырлыгын тою; аның кыенлыгын, тискәре ягын үз тәҗрибәсендә

тату, алдану. *Ул юләрнең сүзен сүз итеп төнәдем* // Берәр эшне эшләгәнгә яки эшләмәгәнгә үкенү

3) Тиешле тәм, төс, консистенция һ.б. барлыкка килү; әзер булу, тиешле дәрәҗәдә әчү (сыра, төнәтмә кебек нәрсәләр тур.). *Тизрәк әчесен, тизрәк төнәсен дип, трахтир сырасын ике шешә итеп салган идем, алай да әле әчеп җитмәгән.* Г.Камал. *Аякларыңны көн саен каен күмере кайнаган суга, спиртта төнәгән сирень төнәтмәсенә тыгып утыр.* А.Хәлим

4) *күч.* Тинтерәү, азаплану. *Җитәкчене көтеп төнәдек*

**ТӨ́Н БАЛЫГЫ** *и. зоол.* Алабугачалар семьялыгыннан күзләре һәм зур авызы өскә карап торган, төнлә актив, көндез күбесенчә диңгез төбендә ком астына яшеренеп ята торган кечерәк диңгез балыгы; *русчасы:* **звездочёт**

**ТӨНБОЕК** *и. бот.* Төнбоекчалар семьялыгыннан тын һәм акрын агымлы суда була, йөрәк сыман эре яфраклары су өстенә җәелеп үсә торган ак яки сары чәчәкле су үсемлеге; тубалчәчәк; *русчасы*: **кувшинка**. *Җиһангир аны баланы күтәргән шикелле күтәрде дә су эчендә үскән биек камышлар, киң яфраклы су үсемлекләре, кар кебек ак төнбоеклар арасыннан ярга таба алып китте.* Г.Әпсәләмов. *Ул, үзенең җиңел гәүдәсе белән яфрактан яфракка сикереп, төнбоек чәчәкләре җыеп ала да такмак әйтүчеләрнең түшләренә кадап чыга икән.* Ф.Яруллин

**ТӨНБОЕКЛЫ** *с.* Төнбоеклар үсә торган. *Әнә ул балык тоткан төнбоеклы Саелмыш суы, әнә Бурлы тау күгәреп тора, аның битләрендә ислекәй, сөтлекәй, андыз чәчәкләре, авыл янында гына Әйләнә күле җәелеп ята.* Г.Әпсәләмов. *Уң якта чәчәкләр тулы чабылмаган болын, сул якта төнбоеклы күл.* Д.Каюмова

**ТӨНБОЕ́КЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Ябык сулыкларда һәм сазлыкларда үсә торган, чәчәкләре ялгыз урнашкан, вак төнбоек, сары төнбоек, ал төнбоек кебек төрләрне берләштергән икеөлешле үлән үсемлекләр семьялыгы; *русчасы:* **кувшинковые**. *Төнбоекчалардан сары төнбоек тамырчаларында туплана торган алкалоидларда хинолизидин боҗрасы фуран боҗрасы белән бергә була, һәм алар нуфаридиннар дип атала.* Агулы үсемлекләр

**ТӨНГЕ** *с.* 1) Төн вакытындагы. *Әллә инде шаярып-көлеп туйганнар, әллә инде төнге шәһәр тынлыгын бозарга кыймыйлар: сүзсез генә атлыйлар да атлыйлар.* Р.Вәлиев. *Төнге урам буйлап атлаган ике милиционерга бәрелә язып узып китсә дә, кичә аны хәтта тәртип сакчылары да туктатмады.* М.Кәбиров

2) Төнлә була, төнлә башкарыла торган. *Дүрт көннән соң төнге сугыш вакытында авыр яраландым һәм сугыштан чыгарга мәҗбүр булдым.* Р.Баттал. *Төнге яңгырның елак тавышын бүлеп, капка келәсе чертләп бикләнде.* А.Әхмәтгалиева

3) Төнлә файдалану өчен билгеләнгән; төнге вакыт өчен махсус эшләнгән, көйләнгән, уйланылган. *Керсә, чалкан китә язган: сакал-мыек баскан Гомәр абзый, кечкенә генә булып бөгәрләнеп, төнге чүлмәк өстендә утыра, ди.* И.Хуҗин. *Мәрьям, бөтен көчен җыеп, тумбочка өстендәге төнге лампа төймәсенә үрелде.* Х.Ибраһим

4) Төнлә эшли торган, төнлә хәрәкәт итә торган. *Өске катка менә торган агач баскычка, читек үкчәсе белән, төнге каравылчы шакылдавыгы тавышы сыман шак-шок басканы ишетелде.* М.Галәү. *Арыш басулары, карабодай кырлары, урманнар, авыллар арасыннан ашыгып-ашыгып, төнге поезд бара!..* А.Гыйләҗев

5) Төнлә килгән, төнлә булып киткән. *Көйдереп ала торган карашлы бу төнге кунак, шунда ук исемен әйтеп, Сәеткә кулын сузды.* М.Хәсәнов

6) Төнлә оча, ауга чыга, чәчәк ата яки башкача активлык күрсәтә торган (кайбер зоология һәм ботаника атамаларының состав өлеше буларак кулланыла). *Төнге чәчәк шикелле ябып торган, кылгандай саргылт чәчле, зур зәңгәр күзле бу туташны Сафагәрәй бер күрүдә ошатты, хатыны итте.* М.Әмирханов. *Манара биеклеген куып җитәргә теләгәндәй сузылып үскән тупылның шәмәхә чуклы, хуш исле ябалдашыннан сузып-сузып аваз салгалаучы төнге кош кисәк тынасы итте.* Л.Зөлкарнәй

◊ **Төнге пәри** *к.* **төн пәрие**. *Минем бу төнге пәриләргә бик ис китеп карап торганны Шиһаби абзый [күрде].* М.Гали

**ТӨНГЕЛЕК** *и.* 1) Төнге вакыт, төн. *Ул, кызны озатып, ишекне төнгелеккә ныгытып бикләп, сабыр атлап, әнисе янына килеп басты.* К.Тимбикова. *Малларга төнгелеккә камыл ташлап, Ярмөхәммәт Зәйтүнәләргә йөгерде.* Р.Батулла

2) *этн.* Мәет янында төнге кизү. *– Хәнифә кодагый, – дип дәште ул Анифә апага, – күрше-тирәгездә татар корткалары бармы? Төнгелеккә утырырга кеше табылырмы?* Х.Сарьян

3) Төнге ял, төнге йокы. *Төнгелеккә атларны куярга өсте ябулы абзары бар.* А.Хәсәнов. *Инде кич тә җитеп килә, төнгелек турында уйларга вакыт иде.* Ф.Бәйрәмова

4) Төнге эш (көтү көтү, балык тоту һ.б.). *Ул хатынына: «Фәндәс дус белән төнгелеккә балыкка барабыз», – диде.* З.Мурсиев. *Төнгелеккә калырга теләгән бердәнбер бала ул.* Г.Гыйльманов

**ТӨНГЕЛЧӘ** *и. диал.* Ябалакчыклар семьялыгыннан кичен һәм төнлә актив тереклек алып бара, ужым ашый торган корт; төнге ябалакчык; *русчасы:* **ночница**

**ТӨНГЕ ЯБАЛАК** *и.* 1) Мәче башлы ябалак. *Каядыр еракта, бик еракта төнге ябалак канат каккан тавышлар ишетелә.* В.Имамов. *Төнге ябалак тавышына да аның елыйсы килә, шулкадәр дә бәгырьне әрнетеп яңгырый бу тавыш.* Г.Гыйльманов

2) *күч. к.* **төн кошы** (*2–3 мәгъ.*). *Хәбибрахман картның, төнге ябалакның, үз шпионнары бармы әллә?* А.Гыйләҗев. *Илһам «төнге ябалаклар»ны шатланып каршы алды, өчебезне берьюлы киң кочагына сыйдырып, өенә әйдәде.* Н.Гыйматдинова

**ТӨ́Н ГӨЛЕ** *и. бот.* Төнгөлчәләр семьялыгыннан алсу, ак, сыек шәмәхә яки кып-кызыл чәчәкләре төнлә генә ачылып, көндез ябыла торган, бүлмә гөле итеп тә үстерелә торган күпьеллык

декоратив үләнчел үсемлек; ахшам гөле; *русчасы:* **ночная красавица**. *Сөбханалла, төн гөле чәчәк аткан!* А.Гыйләҗев. *Әнә тарантас башындагы төн гөлен күр әле, күр*! М.Хуҗин

**ТӨНГӨ́ЛЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Тропикларда һәм субтропикларда киң таралган, матур чәчәк ата һәм декоратив максатларда да үстерелә торган икеөлешле үсемлекләр семьялыгы

**ТӨНДЕК** *и. диал. к.* **төнлек** II. *Төтен чыгар өчен, мичнең ике ягындагы стеналарында кечкенә генә ике төндек тишеге була.* З.Бәшири

**ТӨНЕ́-КӨНЕ** *рәв.* Бөтен тәүлек буенча, төнлә дә, көндез дә; көне-төне. *Син төне-көне тәрәккыйпәрвәрләнергә, җәмәгать эшләренә керергә тырышып йөрисең.* К.Тинчурин. *Төне-көне терлек арасында аунауга караганда, синең колың булу миңа мең артык.* Н.Фәттах

**ТӨНЕН** *рәв.* Төн белән, төнлә, төнне. *Төнен диссертациягә утырмый ярамый.* И.Юзеев. *Көне буе коридор тәрәзәсеннән басу-урманнарга, шәһәр-авылларга карап торды ул, төнен исә өске киштәдә йокысыз тирбәлеп ятты.* М.Маликова

**ТӨ́Н КОШЫ** *и.* 1) Ярканат. *Тора хан кыз күзе алдында куркынган пошы төсле, Кояш алдында тын алмыйча каткан төн кошы төсле.* Г.Тукай. *Әйтерсең лә минем яннан гына, карга тияр-тимәс, биниһая зур төн кошы очып узды.* Сабантуй

2) Күбесенчә төнлә актив тереклек алып бара торган һәртөрле кошлар турында. *Ниндидер төн кошы, җиңел канатларын җилпеп, сугышчыларның баш түбәләреннән генә очып үтте.* Г.Әпсәләмов. *Шул вакытлардан Аккош – көн кошы, Ябалак төн кошы булып киткән.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Төнлә йокламый, актив яшәү рәвеше алып бара торган кеше. *Таң алдыннан йокы кача – Ул төн кошы микәнни?* Ш.Галиев. *Көне гел эштә узган бу карчыкның «төн кошы» булуы, бәлки, шуннан да килә торгандыр.* Туганайлар

4) *күч.* Кеше күзенә күренмичә качып-посып төнлә йөри торган кеше; төнге юлбасар. *Төн кошлары инде ишек төбендә, сак кына шакып куябыз.* Г.Гомәр. *Капка төбендәге эскәмиягә «төн кошы» кунган иде.* Н.Гыйматдинова

**ТӨ́Н-КӨН** *рәв. к.* **көн-төн**. *Төн-көн эчүдән аңгы-миңге утырса да, Ямгырчы бинең тикмәгә генә килмәгәнлеген ул бик яхшы аңлады.* Н.Фәттах. *Каннар агып, төн-көн елап, Үзалдына тузына...* Ф.Яхин

◊ **Төнне-көнне белми(чә)** Бик тырышып, бөтен игътибарын биреп; иң мөһим эш дип санап. *Ярты крүжкә сөт өчен, дөнья беткәндәй ах-ух килеп, төнне-көнне белми тызылдап-бызылдап йөриләр.* Г.Мөхәммәтшин. *Шулай аларның нарасыйлары туа, әти-әни, төнне-көнне белмичә, аларны тәрбияләргә тотына.* Сабантуй. **Төнне-көнне онытып** Бик нык бирелеп, бар нәрсәне онытып (эшләү, йөрү һ.б.ш. тур.). *Мәктәптә укыганда, минем аша ток йөргән кебек иде, ашау-эчүне онытып, шигырь язган чаклар була иде. Көнне-төнне онытып.* Л.Янсуар

**ТӨ́Н КҮБӘЛӘГЕ** *и.* 1) *зоол.* Төнлә оча торган күбәләкләрнең гомуми исеме. *Ләкин фаралар яктысына әледән-әле аксыл соры төн күбәләкләре килеп чыга.* Г.Бәширов. *Бары тик баганалардагы зур лампочкалар тирәли төн күбәләкләре генә әйлән-бәйлән уйнап мәш килә дә, этләр өргәләп куя.* Идел

2) *күч.* Фахишә. *Бу хатын андый төн күбәләгенә охшамаган.* К.Кара. *Тик бу юлы урам чатларында «төн күбәләкләре» күренми, урамнар буп-буш диярлек, тик ара-тирә соңарган машиналар гына үтеп китә.* Р.Зәйдулла

**ТӨ́Н КҮГӘРЧЕНЕ** *и. зоол.* Төн күгәрченнәре семьялыгыннан киң җәенке башлы, зур авызлы, кечкенә томшыклы, төннәрен бөҗәк аулап тереклек итә торган кош; *русчасы:* **козодой**. *Ниһаять, эреп бер якка түнтәйгән, әмма Алла кодрәте белән әле һаман да манара башында утырган ай урагы, төн күгәрчене шикелле, тавышсыз-тынсыз гына түбәнгә – җәһәннәмгә оча.* Т.Мөбарәков. *Төн күгәрченнәренең, ябалакларның соңгы авазларын күмеп, таң кошлары кояшны каршылыйлар.* Р.Юсупова

**ТӨ́НКҮГӘРЧЕНЕСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Эңгер-меңгердә һәм төнлә актив төн күгәрченнәре, бакаавызлар кебек берничә семьялыкны берләштерә торган кошлар отряды; *русчасы*: **козодоеобразные**

**ТӨН КҮГӘРЧЕННӘРЕ** *и. күпл. зоол.* Җирдә оялый һәм күбесенчә төнлә оча, бөҗәкләр белән туклана торган, гади төн күгәрчене, зур төн күгәрчене кебек кошларны берләштергән семьялык; *русчасы*: **козодоевые**. *Төн күгәрченнәре семьялыгына кергән кошлар, ябалаклар кебек, төнлә ауга чыгалар.* Биология

**ТӨ́Н ЛАЧЫНЫ** *и. зоол.* Лачын кошлар семьялыгыннан Евразиянең урман һәм урман-дала зоналарында яши, Африкада кышлый, бөҗәкләр һәм вак тычкансыман кимерүчеләр белән туклана торган ерткыч кош; ягылбай; *русчасы:* **кобчик**. *Зарарлы бөҗәкләр һәм тычканнар аулап, төн лачыны авыл хуҗалыгына зур файда китерә.* Сабантуй

**ТӨНЛӘ** *рәв.* Төнге вакытта, төнне. *Шәһәр малаеның уч төпләре кабарып чыкты, суелган җирләре төнлә ачыттырып-ачыттырып сызлады.* А.Тимергалин. *Күрәсез бит, мунчадан соң Рамил бөтенләй эреп бетеп йоклый, төнлә ник бер уянып карасын...* А.Әхмәтгалиева

◊ **Төнлә туган** 1) Караңгы чырайлы, башкалар белән рәтләп сөйләшми торган кеше турында. *Дөнья турында, кызлар турында аның белән бер сүз алышып булмый иде: әллә нинди төнлә туган нәмәрсә!* А.Гыйләҗев; 2) Акылсыз, юләр яки аңгыра кеше турында. *Күп тә үтмәде, бер олырак яшьтәге апа килеп чыкты да: – Төнлә туган, ник куасың ул сарыкларны? – дип, мине әрли башлады.* Н.Гариф. *Дурак, аңгырабаш, төнлә туган.* Ф.Яруллин; 3) Кеше күрмәгәндә, качып-посып ясалган (көмешкә, исерткеч эчемлек). *Шуның өстенә, һәркемдә – төнлә туган. Хуҗалык һаман да чөгендер үстергәч ни, писугын капчыклап бирә, --- бал кой да, көмешкә чыгарып эч, артыгын сат.* Р.Рысаев. *Шуңа күрә самогонны*

*«төнлә туган» дип йөртәләр икән, белдем инде хәзер.* Туган як

**ТӨНЛӘТЕП** *рәв.* Төнгә каршы, төнлә. *И җаным, үзләре үк төнләтеп берәр җиргә урнаштырганнардыр әле.* А.Вергазов. *Малларны ул кичкегә ашатып япканнан соң, төнләтеп кайтып керер дә таң яктысыннан янә атын җигә башлар иде.* Т.Гарипова

**ТӨНЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Төн үткәрү, төнлә берәр җирдә куну. *Урыс явы беренче төнен Мишәнең аргы ягында төнләгән.* Н.Гариф. *Вә янә төнләдек Каменка районы Муловка авылында.* Гасырлар авазы

2) Төнгә калу, соңлау. *Бүген бик төнләгәнсең*

**ТӨНЛЕК** I *с.* **1.** 1) Төнгә исәпләнгән, караган; төн белән бәйле, төн өчен. *Төнлек эш*

2) Бер төнгә исәпләнгән, бер төнгә җитәрлек, бер төн эчендә башкарырлык. *Безне кабул иткән пар – бик мөлаем яшь мөселман гаиләсе, алар шушы вулканга илтүче иң кыска юлга якын урнашкан Синару шәһәрендә яшиләр, туристларга төнлек бүлмә тәкъдим итәләр.* Сөембикә

3) Эшен төнлә эшли торган. *Фатыйма бикә аны билгеле [бәһа] белән йортҗиренә төнлек каравылчы итмәкче булган.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Төнге вакыт; төнге ял. *Төнлек өчен этне дә бәйләвеннән ычкындырсаң ярый!* Г.Ибраһимов. *Төнлеккә йоклар урын эзләү нияте иде аның.* Н.Каштанов

2) Төнге эш (көтү көтү, балык тоту, кизү тору һ.б.). *Тиреследә хәзер һәр аранда ат пошкыра, малайлар аларны төнлеккә урманга алып китәләр, юлда тояк тавышлары ишетелә, --- шатлыкның эчтә тып-тын тантана итүе – үзе бер өстәмә сөенеч бит ул!* Р.Зәйдулла. *Төнлеккә аның урынына шундый ук таза, елгыр егетләр килә.* Т.Галиуллин

3) Төнлә кабызу өчен кулланыла торган тонык утлы лампа, яктырткыч; *русчасы*: **ночник**. *Лампадалар. Люстра һәм төнлекләр... Бар да кирәк. Бар да асыллар. Ә биредә шуның барчасына Шәм яндырып... ремонт ясыйлар.* З.Нури. *Саша бермәлгә тынсыз калды, бераз тын гына яткач, торып, төнлекне яндырды, түшәмгә карап яткан хатынына карап тора башлады, аның йөзе бик җитди иде.* З.Кадыйрова

**ТӨНЛЕК** II *и.* 1) Морҗасыз өйләрдә яки кара мунчаларда, төтен чыгу өчен, түшәмгә яки диварга ясалган тишек, төтен юлы. *Иң югарыда киңлеге бер аршын ярым чамасында ачыклык калды, бусы төнлек булачак, һава, якты керергә, төтен чыгарырга хезмәт кылачак.* Г.Ибраһимов. *Утын янып, кисәүләре тәмам беткәч, шаулап торган күмерләрне тимер белән болгатып җибәрәсең дә иң башта төнлекне каплыйсың, эссе чыгып качарлык булмасын дип, мунчаланы тыгызлап, төеп куясың.* Р.Батулла

2) Төрле корылмаларда яктылык керү, һава алышыну өчен ясала торган зур булмаган тишек. *Иркен түр бүлмәнең тәрәзәләре көн яктысы кермәслек итеп томалап куелган, капкачы аз гына ачылган түбә-түшәмдәге төнлектән бүлмәнең үзәгенә саран яктылык сирпелә.* Л.Зөлкарнәй // Тәрәзә хезмәтен үти торган зур булмаган тишек, ачыклык. *Анда төнлек тәрәзәсе булса кирәк, ул, билгеле, ватыктыр инде...* Ә.Еники. *Болар кечкенә төнлектәрәзәдән төшкән эңгер-меңгер караңгылыкта калдылар.* Х.Камалов

3) Биналарда, корылмаларда һава алышыну, кирәк очракта, ис һәм төтен чыксын өчен ясала торган махсус тишек. *Андрейны башта ул газ төнлекләре тикшереп йөрүче пожар инспекторы дип белде.* Х.Камалов. *Һава температурасы кинәт һәм еш алышынып тору сәбәпле, төнлек боз белән капланган яисә кар белән күмелгән булуы бар, ә бу, үз чиратында, тарту көче бозылуга китерә.* Заман сулышы

4) Самавыр морҗасыннан чыккан төтенне үткәрү өчен, мичкә махсус ясала торган кечкенә түгәрәк тишек. *[Апа] кече учак төнлегенә торбаны тыгып куйды.* Г.Ахунов. *Кар кебек акшарланган мич буенда, муенын төнлеккә сузып, самавыр җырлап утыра.* Идел

5) *иск.* Шундый тишекне томалау өчен кулланыла торган чүпрәк. *Кешеләрнең авызына төнлек тыгып булмый.* Ә.Фәйзи

◊ **Төнлегеннән җил өрми, ишегеннән кеше керми** Пошмас, беркем белән аралашмас, бернигә дә исе китми торган кешегә карата кулланыла. *Ул бик тыныч яши: төнлегеннән җил өрми, ишегеннән кеше керми.* Н.Исәнбәт. **Төнлек чүпрәге** *мыск.* Ямьсез, котсыз, мәхәббәтсез (хатын-кызны мыскыллап әйтелә)

**ТӨНЛЕКЧЕ** *и.* 1) Төнлә эшләүче кеше. *Төнлекчеләр эштән кайта*

2) *кимс.* Фахишә. *Хактырмы, юкмы, аның турында «байлар аны мунча төнлекчесе итеп тота икән» дигән гайбәт йөри иде.* В.Имамов

**ТӨ́Н МИЛӘҮШӘСЕ** *и. бот.* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан бүлмә гөле буларак та үстерелә, төнлә чәчәк ата торган хуш исле күпьеллык үлән үсемлек; ахшам миләүшәсе; *русчасы*: **вечерница, ночная фиалка**. *Теге якта, түтәл-түтәл итеп, бакча тутырып төн миләүшәләре утыртканнар иде.* А.Гыйләҗев

2) Сәхләбчәләр семьялыгыннан урман аланнарында һәм куаклар арасында үсә торган, ак чәчәкле, төнлә хуш ис тарата торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **любка**. *Төн миләүшәсенең киптерелгән бүлбеләрен медицинада да кулланалар.* Туган як

**ТӨННӘ** *рәв. диал. к.* **төнлә**. *Аннары, барып та, төннә кемгә күрсәтим, кая куйыйм мин ул әнине?* В.Нуруллин. *Әнисен ашыгыч ярдәм төннә алып китте, исәндерме, белмим.* Р.Мулланурова

**ТӨННӘЛЕК** *и. сир.* 1) Төннә булу

2) *к.* **төнгелек** (*4 мәгъ.*). *Ул егет булып үскән чакларда, атларны төннәлеккә я елга буйларына, я әрәмәлеккә илтеп, ә инде иртә белән көтү чыккан вакытта аларны барып алу гадәте бар иде.* Г.Галиев

**ТӨННӘРЕН** *рәв.* Берничә төн буена яки һәр төн, гомумән, төнлә. *Суднолар йөртү кагыйдәсен бозып булса да, тәвәккәлләп кузгалдым һәм көндез дә, төннәрен дә күп тапкырлар йөрелгән таныш юлдан саклык белән китеп бардым.* С.Сабиров. *Басу өстендә ул атнада төннәрен аҗаган уйный, аҗаган да күңелгә шом гына сала.* М.Мәһдиев

**ТӨННӘРЕНДӘ** *рәв. к.* **төннәрен**. *Бу тавышка ул төннәрендә чәчрәп-*

*сискәнеп уяначак.* М.Хәсәнов. *Төннәрендә сугыштан бушаган минутлар булса, окоп почмагына җилкәләребез белән терәләбез дә йолдызлар атылганны күзәтәбез һәм кайчандыр ишеткән кара йолдызлар турындагы әкиятләрне искә төшерәбез.* Г.Рәхим

**ТӨННЕ** *рәв. к.* **төнлә**. *Хәлим төнне озак кына йоклый алмый ятты.* А.Шамов

**ТӨННЕК** *и. диал. к.* **төнлек** II. *Ул тагын көрсенеп куйды, аптырап, төннек каршында басып торды-торды да, авыр аякларын көчкә кузгатып, тар, текә баскычтан аска төшә башлады.* Н.Фәттах. *Плитәнең калай морҗасы төннек тишегеннән чыга икән.* А.Тимергалин

**ТӨ́НОЗЫН** *рәв.* Бөтен төн буенча, кичтән алып таң атканчы. *Чана табаннары сызган эзләр арасында Сауранның төнозын йөренүеннән дә сукмак төшеп җитмәгән.* М.Хуҗин. *Төнозын хәлдән килгәнчә кунак булып, сөйләшеп утырдык.* М.Мирза

**ТӨ́Н ПАТШАСЫ** *и.* 1) *бот.* Кактуслар семьялыгыннан бары тик бер төнгә генә эре, матур һәм хуш исле чәчәк ата торган үсемлек; *русчасы*: **царица ночи**. *Дөньядагы барлык телләрдә «төн патшасы» дип аталган бу кактусның хуш исле ак чәчәге нибары бер төн тора, һәм ул аш тәлинкәсе зурлыгында була.* Ш.Хөсәенов

2) *күч.* Гадәттә төнлә барлыкка килә, күренә, була торган кем яки нәрсә. *Җир өстенә төн патшасы ак ай калка.* Т.Миңнуллин

**ТӨ́Н ПӘРИЕ** *и. сөйл.* Төнлә йөри, нәрсәдер эшли торган кешегә карата яратмыйча әйтелә. *Кем булсын – төн пәрие Шәфыйк, директор.* Җ.Юныс. *Нишләп йөрисең, ә, төн пәрие? Лунатик булдың мәллә?* Җ.Рәхимов

**ТӨНСЕЗ** *рәв.* Төн җитмичә, төн булмый торып. *Кечесе фермада, төнсез кайтмый.* В.Нуруллин. *Әтиләре төнсез кайтып кермәс.* Д.Булатова

**ТӨНТӘЮ** *ф. диал.* 1) Иелеп түбәнгә карау, түбәнгә авышу, бөгелү. *Ул берсенә берсе капма-каршы сүзләр сөйләде, үзе, башын тота алмыйча, алга төнтәйде, туктаусыз төкеренде.* Г.Галиев. *Рәхимҗан, төнтәеп, өйләренә атлады.* Н.Гыйматдинова

2) *к.* **төнтекләнү**. *Төнтек төнтәеп йөрер.* Мәкаль

**ТӨНТЕК** *с.* **1.** 1) Караңгы чырайлы, башкалар белән аралашмый, сөйләшми торган. *Болай сүзсез, төнтек, мокыт адәм түгел идең ләбаса син, Шәрифҗан!..* А.Гыйләҗев. *Ире, үзе саусәламәт булса да, чыннан да, төнтек, пешмәгән бер бәндә аның.* В.Нуруллин

2) Караңгы, төксе (йөз, чырай тур.). *Кибет эчендә дә чырае төнтек иде аның, сүзсез генә үлчәде, сүзсез генә акча санады.* Н.Гыйматдинова

3) Караңгы, кысан, кечкенә, шыксыз (бүлмә, яшәү урыны тур.). *Моннан ары да шушы төнтек бүлмәгездә адәм чырае күрми яшәячәксез.* Ю.Сафиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Караңгы йөз белән, якты чырай күрсәтмичә. *Хуҗа төнтек йөрсә, солдатка бик авыр була.* И.Гази

**3.** *и. мәгъ.* Гел караңгы чырай белән йөргән кеше. *Кичә Гали төнтек тагын аларга барып кергәндер...* А.Гыйләҗев. *– Атып кына үтеримче, иптәш Гайсин, шушы төнтекне? – диде сакчы, картка ачуыннан тәмам калтырана башлап.* В.Нуруллин

**ТӨНТЕКЛӘНҮ** *ф.* Төкселәнү, чыраен сыту, йөзен җимерү. *Бер нәрсә сөйләшми диярлек, чыга, кайта, урамда очраганнарга сәлам бирми, төнтекләнеп, башын иеп читкә карап уза, өйдә чакта күбрәк вакытын көзге каршысында үткәрә.* А.Гыйләҗев. *Ләкин Коляның бер авыз сүз әйтмичә төнтекләнеп чыгып китүе...* А.Тимергалин

**ТӨ́Н УБЫРЫ** *и. сөйл. к.* **төн пәрие**. *Кайсы төн убыры йөри инде бу вакытта?* Н.Әхмәдиев. *Бу тоттырмас шымчы, төн убыры, шушы яңгыр астында да кайдадыр йөри микәнни?* Р.Вәлиев

**ТӨ́Н ЧИБӘРЕ** *и. бот. к.* **төн гөле**

**ТӨ́НЬЯК** *и.* **1.** 1) Дөньяның дүрт тарафының берсе; көньякка капма-каршы як. *Тәрәзә төньякка карый. Төньякка таба киттеләр*

2) Илнең, дәүләтнең, коры җирнең, шәһәр-авылның һ.б.ш.ның шул юнәлештә яткан өлеше, урыны. *Күлнең көньягында да тау, төньягында да тау – гүя ул кайчандыр тоташ булган зур тауны икегә аерган да шуларның уртасына кереп яткан.* Ә.Еники. *Мәгълүм ки, Дунай тамагында, Византиянең төньягында, борын-борыннан төрле-төрле кабиләләр, халыклар яшәгән, аларның дәвамнары безнең көннәргә дә килеп җиткән.* Т.Әйди

3) Салкын һәм уртача салкын климатлы зонада урнашкан территория. *Төньяк турында Илмира бик яратып һәм сокланып сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Синең белән дус булыр өчен, төньякка китәргә кирәк.* А.Гыйләҗев

4) Европа һәм Азия материкларының салкын климатлы кырыенда урнашкан, Җир шарының шул зона белән янәшә яткан поляр өлкәсе. *Радмир, нефть эзләп, Төньякка чыгып китте.* Г.Мирһади. *[Артур Чилингаров] Көньяк Котыпта да, Төньякта да булган кеше.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый зонага хас булган; шул якка мөнәсәбәтле булган. *Ул Төньяк манарада ишек сакчысы булып эшләгән.* А.Гыйльми

2) Шундый зонада урнашкан. *Безнең яшьләр БАМ төзи, КамАЗ төзи, җәяүләп, чаңгыда Төньяк полюска бара.* М.Мәһдиев. *Хәер, бу очракта төньяк ярымшарның Кояш яктысын мулрак алуы күздә тотылган.* А.Тимергалин

3) Шул якта, шул зонада яши, эшли, хәрәкәт итә торган. *Төньяк флот*

4) Кайбер изафәле зоология атамаларының состав кисәге буларак кулланыла. *Җылы яратучы җәнлекләр үлеп беткән, алар урынына мамонтлар, йонтәс мөгезборыннар, мәгарә аюлары, төньяк боланнары, ак төлкеләр үрчегән.* Р.Фәхретдинов. *Ак аю (аны төньяк аюы, поляр аю, диңгез аюы дип тә йөртәләр) – иң зур ерткыч хайваннарның берсе.* Көмеш кыңгырау

**ТӨ́НЬЯК-КӨНБАТЫШ** *и.* **1.** 1) Горизонтның төньяк һәм көнбатыш тарафлары арасындагы өлеше, төньяк һәм көнбатыш арасындагы юнәлеш. *Ләкин, сазлык аркылы үтергә куркып, төньяк-көнбатышка борылганнар.* Г.Әпсәләмов. *Төньяк-көнбатыштан искән җил Мисырга шифалы дым һәм талгынлык алып килә.* Н.Фәттах

2) Коры җирнең, дәүләт, ил, шәһәр-авыл һ.б.ш.ларның шул юнәлештә урнашкан ягы. *Бу кодрәтле мәмләкәт составына хәзерге Кытайның төньяк-көнбатышы, Кыргызстан, Казакъстанның зур өлеше һәм Урта Азиядәге кайбер башка төбәкләр керә.* Х.Миңнегулов. *Евразиянең төньяк-көнбатышы күлләргә аеруча бай.* География

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул юнәлештәге, шул якта урнашкан. *Угланы әмир Хаҗи, төньяк-көнбатыш тарафтагы чикләрне ныгыту исәбе белән, Казан елгасының өске ягынарак кирмән салды.* М.Хәбибуллин. *Шулай да аның исән калган көчләре төньяк-көнбатыш яктан шәһәрне калдырып чигенергә җай таптылар.* М.Хәмитов

2) Шул юнәлештә хәрәкәт итә торган. *Янәсе, аның безгә ни хаҗәте булыр икән, аны үзебезнең төньяк-көнбатыш фронттан табып, редакциягә китертә алганы өчен, Хатип ник куана икән?* М.Яһудин

3) Шул яктан исә торган. *Төньяк-көнбатыш җил урыны белән 10–15 м/ска кадәр көчәергә мөмкин.* Ватаным Татарстан

**ТӨ́НЬЯК-КӨНЧЫГЫШ** *и.* **1.** 1) Горизонтның төньяк һәм көнчыгыш тарафлары арасындагы өлеше, төньяк һәм көнчыгыш арасындагы юнәлеш. *Хәтерем ялгышмаса, Сөембикә манарасының төньяк-көнчыгышка таба авышлыгы метр да җитмеш сантиметрга җитеп килә иде.* А.Тимергалин. *Төньяк-көнчыгышта алар Кытай белән чикләнгән булганнар һәм Кытай белән икътисади һәм мәдәни бәйләнешләргә кергәннәр.* И.Хуҗин

2) Коры җирнең, дәүләт, ил, шәһәр-авыл һ.б.ш.ларның шул юнәлештә урнашкан ягы. *Бу коңгызның ватаны – Мексиканың төньяк-көнчыгышы.* Кызыл таң. *Быелгы контракт буенча без бу Ми-2 вертолётын республиканың төньяк-көнчыгышы өчен дә кулланачакбыз.* Шәһри Чаллы

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул юнәлештәге, шул якта урнашкан. *Байкал артындагы ерак далада һәм Монголиянең төньяк-көнчыгыш районнарында киләчәктә бөтен дөньяны тетрәндерәчәк башлангыч феодаль дәүләт барлыкка килә.* Т.Кәримов

2) Шул юнәлештә хәрәкәт итә торган. *Ул төньяк-көнчыгыш фронт гаскәрләре составында 1940 ның 3–9 мартында хәзерге Выборг шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә.* Мәйдан

3) Шул яктан исә торган. *Көндез төньяк-көнчыгыш җил 20 м/с ка кадәр җитәчәк, буран чыгачак.* Татарстан яшьләре

**ТӨ́НЬЯКЛАП** *рәв.* Төньяктан, төньяк юнәлештән. *Таң алдыннан төньяклап искән аяз җил аяк астын чиратты.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Мәсәлән, бу җәйдә алар Уфаның Затон бистәсен төньяклап урап үтүче магистраль автоюлын салуда актив катнаша.* Кызыл таң

**ТӨ́Н ЯБАЛАГЫ** *и. сөйл. к.* **төн кошы** (*3 мәгъ.*). *Ә-ә-ә, син дә мондамыни әле, төн ябалагы, Питрәч чәүкәсе.* Г.Мөхәммәтшин. *Үз әти-әнисе берни белми, сез, төн ябалаклары, барын белеп, тикшереп торасыз тагын.* А.Гыйләҗев

**ТӨҢГЕР** *и. этн.* Күн тартылган һәм кырыйларына шөлдерләр, вак калайлар беркетелгән түгәрәк кысадан гыйбарәт бәрмә музыка коралы; дөңгер; *русчасы:* **бубен**. *Туй үткәч – төңгер.* Мәкаль. *Калач (кәләч) дип, башта төңгер (түгәрәк барабан «бубен») кысасын атаганнар, шуңа охшаш икмәкне юл азыгы итеп пешергәннәр.* Р.Әхмәтьянов

**ТӨП** *и.* **1.** 1) Диңгез, күл, елга һ.б.ш. сулыкларның аскы яссылыгы, аскы чиге. *Ташулар бетүгә үк, көймәле кешеләр көймә белән эчкә кереп, көймәсезләр яр кырыеннан багорлар белән елга төбен актардылар.* Ф.Яруллин. *Океан төбендә аткан вулканнан туган дәһшәтле дулкын меңнәрчә чакрымны үтә, хәтта дөньяны әйләнеп чыга, берзаман дулкыннар тәбәнәкләнә, көчсезләнә, юашлана.* Р.Газиз

2) Җир өстендәге батынкы урынның, чокырның, казылган җирнең түбәнге өлеше. *Тончыга башлавын тоеп, күкрәген тутырып һава алмакчы иде дә, искәрмәстән генә бугазына ялкынлы кисәү тыгып куйдылармыни, кинәт күз аллары караңгыланып китте, егылмас өчен, янә окоп төбенә чүгәргә мәҗбүр булды.* М.Хәсәнов. *Нәкъ аның каршында, тирән чокыр төбендә, бер зур болан ята иде.* М.Әмирханов

3) Вертикаль сызыкның аска таба караган юнәлеше; ас. *Сизәм: юеш кием мине төпкә тарта, йөзәргә комачаулый.* С.Сабиров. *Төптә су ялтыраганы күренми, кое күптән кипкән шикелле.* А.Тимергалин

4) Зур, чиксез массаның, киңлекнең, массивның иң тирән җире; тирәнлек. *Каяндыр еравктан, җирнең төбеннән, челтерәп чишмә агып чыкканы ишетелә.* Ф.Бәйрәмова

5) Берәр нәрсәнең аскы өлеше. *Тимур кесәсеннән бер уч ак төймәләр тартып чыгарып, Камиләнең борын төбендә уйнатып алды.* Ф.Бәйрәмова. *Иң ахырдан Рәшит, кулларын йодрыклап, аның ияк төбенә кундырды.* Р.Галиуллин

6) Сыеклык, балчык, җир, вак масса һ.б.ш.ларның өске катламнарыннан эчтәрәк, тирәндә урнашкан урыны

7) Берәр нәрсәнең тышкы чигеннән еракта, эчтә, түрдә торган урыны; түр. *Чәйне тәмамлап, тирән табакта шылтырдатып чынаяклар чайкаштырган Өммегөлсем карчык күкрәк төбеннән чыккан нәзберек, газаплы аһәң белән сорап куйды: – Я, карт, әйт соңгы сүзеңне...* А.Хәлим. *Ләкин Валия куәт белән бәреп чыгарга теләгән үксү гайрәтен бугаз төбендә тотып торырга көч таба.* Р.Батулла

8) Эче куыш нәрсәләрнең түбәнге ягы, эчке яктагы асты, түбәнге стенасы. *– Үзе йодрык кадәрле генә, ә бер чәркә ашны суктырды да куйды, – дип сукранды хатын, песи савыт төбен ялаганда.* Ә.Моталлапов. *«Сөлгене сандык төбенә салмагыз, саргая...» – ди торган иде ул...* Л.Зөлкарнәй // Эче куыш әйберләрнең асты. *Урамда кемдер чиләк төбе кагарга тотынгач, халык кычкырыша башлагач, берьюлы сикереп тордылар, аннан-моннан гына киенеп, йөгереп чыктылар.* Г.Гыйльманов

9) Аяк киеменең табан асты өлеше; олтан. *– Нәсимә бик озак кайтмый бүген, – диде Нәгыймь, без белән итек төбен каезлап.* З.Хәким. *Салкын көн-*

*нәр итек төбен ашый, Бит очларын өзә кышның кызы ---.* Ф.Яхин

10) Кулланганнан соң кимегән нәрсәнең кечерәйгән аскы өлеше, калдыгы. *Шомартылмаган такталардан ясалган өстәлдә шәм төбе янып тора.* Г.Әпсәләмов. *Әкрәм килеп кергәндә, кәефе кырылган нәчәлник өстәлгә карандаш төбе белән бәргәләп, дөңгеләтеп утыра иде.* Р.Сәгъди

11) Бәлеш, икмәк һ.б.ш. нәрсәләрнең аскы катламы. *Мин гел көйгән ипи төбе ашадым.* Б.Ислам. *Ризык-нигъмәт мул иде: каткан сырдан алып, кипкән бәлеш төбенә кадәр бар иде.* Л.Лерон

12) Берәр җайланманың, корылманың түбәнге аркылы өлеше. *Ишек төбе тар булганга, анда берьюлы берничә кеше эшли алмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Ул, утә-утешкә, куперенке коңгырт чәчләрен төзәткәләп алырга, тәрәзә төбендә яткан китапны пыяла ишекле шкафка куярга, биек аркалы иске урындыкны стена буена шуыштырырга өлгерде.* А.Әхмәтгалиева

13) Киемнәрнең яисә шуңа охшаш нәрсәләрнең балак, җиң кебек ике яки берничә өлеше тоташкан урыны. *Биктимер аны чалбар төбеннән тартып сөйрәп чыгара.* А.Алиш. *Наилә стенага аркасын терәп, сулкылдап елап тора, күз каймалары күгәргән, күлмәгенең җиң төбе умырылып чыккан.* А.Гыйләҗев

14) Аяк, кул кебек әгъзаларның гәүдә белән тоташкан урыны. *Брезент киемнән, бот төбеннән резин итектән су алгыч чокырында шаптор-шоптыр суда йөргән эшчеләр Булатовның күз алдыннан китми торган булдылар.* А.Алиш. *Ходам сакласын, сиңа кутәрелгән кул төбеннән череп төшәр иде.* Р.Батулла

15) Берәр нәрсәнең икенче бер зуррак нәрсәгә тоташкан урыны. *Тәртә төбе*

16) Яны, ышыгы, якыны. *Сарай төбе*

17) Үсемлекләрнең тамыры. *[Атлар] былтырдан калган коры үләннәрне, төптән баш күтәреп килгән яңа яшел үләннәргә катнаштырып, комсызлык белән кимерергә керештеләр.* Ш.Камал

18) Кискәннән, чапканнан соң үсемлекнең тамырда утырып калган өлеше. *Аяк астына эләккән таш кисәкләре, үлән төпләре аякларны чәнчеп авырттыра.* Ш.Камал

19) Кәүсәсен кискәч яки сындыргач, агачның тамырда утырып калган өлеше; түмгәк. – *Бәхетле булыгыз! – диде Шүрәле һәм шомарып ташка әйләнгән имән төбе ягына китеп барды.* Р.Батулла. *Утырып торырга агач төбе дә тора.* Г.Гыйльманов

20) Агач, куак, үлән үсемлекләрне санау берәмлеге; данә. *Менә бу әбигә егерме биш төп агач җибәрергә ордер яз.* Т.Гыйззәт. *Кемдер баш очына бер төп каен утырткан икән, анысы, яшелсаргылт вак яфраклар чыгарып, үсәргә азаплана.* М.Мәһдиев

21) Зур, биек нәрсәләрнең каплап, күләгәләп торган аскы яны. *Бер минуттан ул инде карт имәннең төбендә, үзенең җилкәсенә генә салып чыккан пальтосын ташлап, Зыяның куенына, зур толыбы эченә атылган иде.* Г.Ибраһимов. *Шулчак чүмәлә төбеннән ябырылып елан көтүе чыкты, алар бөтерелә-бөтерелә ыслыйлар, чәбәләнәләр, бер-берсенә уралалар, ни кылырга белми бәргәләнәләр иде.* М.Хәбибуллин

22) Берәр корылма, бина һ.б.ш.ларның якын-тирәсе, яны. *Озатып капка төбенә кайткач та, күбрәк Галия сөйли.* Г.Галиев. *Теге вакытта вокзал төбендә ике көн көтеп утырдым бит...* Г.Гыйльманов

23) *иск.* Китап яки дәфтәрнең төпләнгән урыны; берәр әсәрнең яки әсәрләрнең аерым китап итеп төпләнгән өлеше; том. *Романның беренче төбе*

24) *күч.* Йөрәк, күңел, рух һ.б.ш.ларның иң яшерен урыны, түре, төпкеле. *Каяндыр астан, йөрәк төбеннән бер төер күтәрелеп, Низамны буып бимазалый башлады.* М.Хәсәнов. *Күңел төбендә пыскып яткан өмет, бәхет кебек изге төшенчәләрне өскәрәк калкытып, әзерләп куйды.* Г.Гыйльманов

25) *күч.* Берәр эш-хәлнең, күренешнең чыганагы, сәбәбе, нигезе. *Эшнең төбе дүрт кабиләнең арасындагы берлекне саклауда һәм менә шул ике уртадагыларны үз ягына аударуда иде.* Г.Ибраһимов. *Яшьрәк кешеләр аны никадәр идеал белән буяп --- маташсалар да, барыбер инде аның төбе шул хайваниятькә, ирлек-хатынлыкка кайтып кала бит, ахрысы!* Г.Рәхим // Берәр эш-хәлнең, күренешнең башка күренешләр, кешеләр һ.б. белән эчке бәйләнешләрен һәм мөнәсәбәтләрен билгели торган нигезе, асылы, эчтәлеге. *Сернең төбе хәл-әхвәлләр белешүдән соң ук шактый ачыкланды.* В.Имамов. *Икенчедән, Зилзилә, мәсьәләнең төбенә төшеп җитмичә, һич хаксызга аңа бәйләнде, өйнең матурлыгын җуйды.* Р.Гарипов

26) *күч.* Берәр нәрсәнең, эш-хәлнең таянычы, нигезе. *Синең тормышыңның төбе булган [кешеләр] череп аугач, сиңа да озакламый дөнья белән исәпләшергә тугры килә түгелме соң?* Х.Кәрим

27) *күч.* Нәсел-нәсәп, килеп чыгыш; тамыр, асыл. *Без бит төбебез белән Көнчыгыштан килгән халык, ә анда һәр гаилә балык үстерә.* А.Нәҗми. *Телебез татар икән, димәк, төбебез татар.* Ватаным Татарстан

28) *күч.* Берәр эш-хәлнең ахыры, азагы, нәтиҗәсе. *Эшнең башы хәерле булса, төбе дә хәерле булыр.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* 1) Иң мөһим, иң әһәмиятле; беренчел. *Монда беренче чиратта кем дус, кем яшерен дошман икәнен белү төп бурыч булып тора.* Г.Тавлин. *Татарча чыккан төп басмаларны җентекләп укып баручы буларак, андый фикер белән килешеп үк бетмәс идем.* Р.Фәйзуллин

2) Үз ишләре арасында иң мөһим, иң әһәмиятле; абруйлы, хөрмәтле, танылган; иң зур эш, роль, партия һ.б.ш.ларны башкара торган. *Ә хатыны Маһруйбикә апа спектакльләрдә гел төп рольләрне башкара.* Г.Гомәр. *Өченче татар профессиональ труппасының төп артисты һәм режиссёры булып танылгач кына, Мутин ялгыз гастрольләрен ташлый, һәм шул вакыттан аның иҗатының яңа чоры башлана.* М.Арсланов

3) Кирәклеге, тиешлеге, әһәмиятлелеге, күләме һ.б.ш. ягы белән беренче чиратта булган. *Әгәр иртәгә дә, берсекөнгә дә шулай эшли башласак, сез үзегез үк моңа юл куймаячаксыз, чөнки сезнең үзегезнең төп эшегез бар.* Г.Әпсәләмов. *Төп белгечлеге инженер булган Әләметдин Җамалетдинович,*

*машинасыннан төшеп, әйләнә-әйләнә, минем йөкне карады ---.* Н.Нәҗмиев

4) Билгеле бер урында гомер-гомергә, буыннан-буынга, күптәннән, даими рәвештә яшәп килгән, җирле (кешеләр тур.). *Ул төп бу авыл кешесе түгел, читтән күчеп кайткан бит.* Р.Вәлиев

5) Элек-электән, күптәннән кемнәрнекедер булган, кем дә булса яшәп килгән; үз. *Рига – XI йөзләрдә салынган шәһәр. Төп латыш шәһәре.* Г.Гали. *Җомга көн кич белән урамнарда кеше аягы басылгач, Мирвәли, Шәмсегаянны ияртеп, төп йортка кайтты.* А.Гыйләҗев

6) Авторның үз телендә язылган, башка телдән тәрҗемә ителмәгән; оригиналь. *Тәүфикъ Әйдигә Урта Азия, Кытай эчендә калган Көнчыгыш Уйгурстан турында язу да җиңел бирелә, чөнки ул аларның телен белә, казах, үзбәк, уйгурларның китапларын төп нөсхәсендә укый, аларның холык-фигыле аңа якын, аңлаешлы.* Б.Рәхимова. *Төп тексттагы иҗекләрнең ныклыгын күрсин!* А.Хәсәнов

7) Берәр нәрсәнең, күренешнең нигезен, асылын тәшкил иткән, нигез булып торган. *Димәк, автор эпиграф ярдәмендә төп эчтәлеккә өстәмә рәвештә яңа эчтәлек тудыра.* Г.Гайнуллина. *Теләкләре зур, төп кызыксындыру чарасы: гарәп телен гарәп кешесе үзе укыта.* Татарстан яшьләре

8) Кешеләрнең, җанлы-җансыз нәрсәләрнең күбесен, әһәмиятлесен үзендә туплаган, үз эченә алган; зур. *Биология күзлегеннән караганда, ирләр – алдан баручы лидер, адәми затның алгарышында төп көч.* А.Тимергалин. *Полкның төп составы дүрт катлы иске зур кирпеч бинада урнашкан иде.* И.Хуҗин

◊ **Төбенә кадәр (чаклы, тикле, хәтле)** 1) Бөтенләй, беткәнче, тулысынча. *Ул стаканны төбенә кадәр эчеп җибәрде һәм кызыл башлы сөлге белән сакал-мыегын сөртте.* Г.Әпсәләмов; 2) Бөтен киңлегенә, озынлыгына, ахырына кадәр. *Балта осталары ишек алдын бер кат әйләнгәч, төбенә кадәр ишекләре ачык тора торган корпуска кереп әйләнеп чыктылар.* М.Гали. **Төбенә тәмәке салу (кою)** *к.* **төбенә төшү**. **Төбенә тоз салу (кою)** *к.* **төбенә төшү**. *Берәр теманы әләктереп алса, журналист халкы, кем әйтмешли, төбенә тоз коярга ярата.* Ватаным Татарстан. **Төбенә төшү** Үтә ваклап, җентекләп берәр нәрсәне ачыклау; төпчену, чокчыну. *Төбенә төшеп сораштылар, барын да төпчerdеләр.* Т.Таһиров. *Ничә көннәр эзләнеп, төбенә төшеп ачыкланган бу эшне ябарга вакыт иде инде.* Казан утлары. **Төп башына утырту** Кемгә дә булса вәгъдә, сүз биреп тә, шул вәгъдәне, сүзне үтәмәү һәм үтәргә дә уйламау, кешене көлке яки авыр хәлгә калдыру; алдау. *Туктале, улым, әллә безне төп башына утыртканнармы?* Г.Ахунов. *Ләкин колхозны ташлап киткән кешеләр – председательне төп башына утырттык, дип көлүчеләр бит алар.* В.Нуруллин. **Төп башына утыру** Кешеләр алдында көлке яки авыр хәлдә калу; алдану. *Безнең Фазылҗанов, мөгаен, төп башына утырып калыр.* Ф.Хөсни. *Аңа ышанып барсам, төп башына утырып калмам микән соң?* Сөембикә. *Быел авыл халкы күгәрчен хәтле тавык чебиләрен 135әр сумга сатып алып төп башына утырды.* Татарстан яшьләре. **Төп башында йорты, казык башында казаны** Йортҗирсез кеше турында. **Төпкә җигелеп тарту** *к.* **төпкә җигелү**. *Нефть осталары килгән, эшнең иң авырын, төпкә җигелеп, алар тарта.* Р.Төхфәтуллин. *--- бик иртә нужа камытын киеп, тормыш йөген төпкә җигелеп тарта башлаган яшүсмерләрне дә онытмаска кирәк!* Ш.Мостафин. **Төпкә җигелү** Төп авырлыкны үз өстенә йөкләү, эшнең авырын үзе башкару. *Килен төпкә җигелгән ул безнең.* Г.Бәширов. *Әнә бит ниләр язалар: милләт файдасына төпкә җигелеп эшләргә вакыт җиткәч, үзара ызгыш-талаш белән мәшгульләр.* С.Сабиров. *Ул инде, элеккe еллардагы кебек, әнисе Гыйльмиса җиңги тапканга ышанып торырга гына теләми, тормышның авырлыгын әнисе җилкәсеннән күбрәк үз җилкәсенә күчереп, үзе төпкә җигелергә уйлый.* М.Гали. **Төпкә килеп төртелү** Берәр каршылыкка очрап тукталып калу, эш терәлү. *Муса бу мәсьәләнең шушылай төпкә килеп төртеләчәген алдан ук сизгән.* Ш.Маннур. **Төпкә төшү** Рухи яктан кирегә китү, әхлак, әдәп кагыйдәләрен оныту, шәхес буларак таркалу. *Шундый типларның ничек итеп төпкә төшүен күрү өчен, мисал итеп Баронны алырга була. Ул – югары сыйныф ташландыкларының вәкиле.* Г.Нигъмәти. **Төпкә утырту** *к.* **төп башына утырту**. *Хәйретдин абзыйны төпкә утыртканнар әле: аның белән бергә колхозга кер, атың белән бергә булырсың, дип кертkәннәр дә, атының аягын бәреп сындырып, аксатып, суеп ашаганнар.* Ш.Маннур. **Төпкә утыру** *к.* **төп башына утыру**. **Төп кебек** Сәламәт, көчле, нык гәүдәле; кыска буйлы, базык. *Безнең арада хәрби диңгезче формасы кигән, төп кебек нык гәүдәле, түп-түгәрәк битле, дәү авызлы бер егет тә бар ---.* В. Нуруллин. *Уң канат ягыннан олы кара атта төп кебек бер пәһлеван бире таба күтәрелеп килә иде.* Ф.Яхин. *Төп кебек Миннәхмәт озын торыклы малайны күтәреп тә алды, нарат бүрәнәле стенага китереп тә бәрде.* Р.Газиз. **Төп кочаклату** *к.* **төп башына утырту**. **Төп күтәрә** *диал.* Тоташы белән, бөтен килеш; тулаем, барысын да, тулысынча. *Без алтыннарның урынын күрсәтәбез икән, аны да, рәхәтләнеп, төп күтәрә сыпырып алачаклар.* Ш.Камал. **Төп тә бер, калкан да бер, чүп тә бер, боламык та бер** Берни аермаучы, талымсыз кешегә карата. **Төптән җигелеп тарту** *к.* **төпкә җигелү**. *Бер яктан, ул бәхетле: үзе исән вакытта ук, гаҗәеп үзенчәлекле талант иясе буларак танылa, шөһрәт казана, милли әдәбиятыбыз йөген төптән җигелеп тартучы фидакяр затлардан санала.* Р.Әмирхан. **Төптән каеру** Җитди эшләү, зур эшләр башкару. *[Миргали] бу кешеләрнең бер дә кабаланмыйча, ыгы-зыгы килмичә нинди зур оешытыру эшләре алып баруларына сокланды: «Төптән каералар икән», – дип уйлап алды.* М.Хәсәнов. **Төптән кисү** *к.* **төптән урдыру**. *Министр Хәким Насыйбович яшьли төптән кисүчән, башны югарыда йөртүчән иде.* Ф.Яхин. **Төптән куркып түмгәккә абынган** Бер бәладән куркып, бөтен игътибарын аңа

юнәлтүдән икенче бәлагә юлыгуны сизми калу. **Төптән урдыру** Артык кискен эш итү, эштә кырыс, коры булу. *Яңа себерке шәп себерә, яңа начальник төптән урдырырга ярата.* А.Гыйләҗев. **Төптән юан үскән** *к.* **төптән юан чыккан**. **Төптән юан чыккан** Таза, нык, базык гәүдәле, карсак кеше турында. *Төптән юан чыккан, казакъка охшаганрак бу малай да Сабир кулыннан күп җәбер күрде.* З.Зәйнуллин. *Менә төптән юан чыгып, аркылыга җәелгән гәүдәләре өстенә кадап куйган кечкенә генә йомры башлы һәм үзүзләреннән бик канәгать кыяфәттәге бай абзыйлар.* М.Гали. **Төп төбендә** Асылда, чынлыкта. **Төп тумран** Юан, тәбәнәк гәүдәле кеше турында. **Төп шикелле** *к.* **төп кебек**. *Аягына чабата, өстенә иске генә чикмән кигән һәм төп шикелле тәбәнәк, таза, сакаллы бер кеше үзенә каршы көрәшергә чыккан берен җиңел генә күтәреп алып җиргә сала тора.* М.Галәү

**ТӨП-** *кис.* Кайбер сыйфатлар яки рәвешләр белән килеп, аларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Менә ул, ялтырап торган озын артыш таягына ике кулы белән таянып, төптөз утыра.* Г.Бәширов. *Димәк, бу вакыйга төп-төгәл егерме тугызынчы августта булган.* Ф.Галиев. *Бер фикер язмак булып, эзлим миемнән мәгънәләр [Әмма сүзләр] --- төп-төче!* Шура

**ТӨ́П АШКАЗАНЫ** *и. зоол.* Күшәүче хайваннар ашказанының дүртенче бүлеге; *русчасы*: **сычуг**. *Кайбер үсемлекләрнең озын төкле яки нык җепсел сабаклары, озын төкле чәчәкләре, җимешләре һәм орлыклары яшь хайваннарның (гадәттә бер яшькә кадәрге сарык бәрәннәренең, бозауларның, тайларның) төп ашказанында (сычугта) күгәрчен, тавык йомыркасы кадәр зурлыкта шарсыман оешкылар (фитобезоарлар) барлыкка китерәләр.* Агулы үсемлекләр

**ТӨ́П БАШЫ** *и.* Бүрәнәнең төптән кисеп алынган юан очы; *русчасы*: **комель**. *Кайтыр алдыннан кесәләрдән салкын ит белән тәмле ипи алып, аны төп башына утырып ашадык.* Г.Мөхәммәтшин. *Киселеп чыккан агач урынында кинәт бөтерелде дә, төп башы белән уйнаклап килеп, Миңнеханның күкрәк өстенә ятты.* В.Имамов

**ТӨ́П БИКЛӘҮ** *ф. бот.* Үсемлек тамыр җибәреп, җиргә берегеп үсеп китү. *Шуңадыр, анда чыршылар бик авырдан төп бикләп китәләр.* Р.Зарипов. *Уңыш түбәнрәк була, һәм кайбер үрентеләр төп бикли алмаска мөмкин.* Ф.Зыятдинов

**ТӨПЕК** *с. диал.* Кыска буйлы, юан гәүдәле. *Ул үзенең шушы төпек кенә кара хатынны --- нишләптер дошман күрүен, нишләптер аннан чиркәнүен тойды.* Н.Фәттах

**ТӨП ЙОРТ** *и.* 1) Гаиләдә, ыруда иң өлкән кардәш яшәгән, гадәттә ата-бабадан калган йорт, нигез. *Тик никадәр тырышып эшләсә дә, төп йортта озак яши алмады.* Г.Бәширов. *Туең булса, балаң туса, өй котлап, Төп йортыңа төшсә ябь-яшь киленнәр, Нинди шатлык – синең якын дуслар Кочак тулы чәчәк тояп килерләр.* Г.Рәхим

2) Ата-бабадан килгән ватан, борынгы ата-бабадан бирле биләп килгән дәүләт; туган җир. *Төп туган йорт – Идел-йорт, Идел эче имин йорт, Атам кияү булган йорт, Анам килен булган йорт, Кендек каным тамган йорт, Ач тамагым туйган йорт.* Дастан

3) *күч.* Теге дөнья, ахирәт. *Килүчеләрнең китми калганы бармы? Ә аннан кире кайтасы түгел. Ул – төп йорт, асыл ватан.* Ф.Яхин

◊ **Төп йортка китү** Үлү, вафат булу. *Авыл халкының яртысы инде күптән төп йортка китте, хәлләре – өч чакрымдагы пүчинкәдә.* Мәдәни җомга

**ТӨПКӘ** I *и. сир.* Агачның кискәннән яки сындырганнан соң тамырында калган аскы өлеше; төп. – *Яшим мин, – дигән бер Төпкә, – Тамырларым күпкә!.. Ә карасаң төптән: Череп беткән күптән.* Ә.Исхак

**ТӨПКӘ** II *рәв.* 1) Бер арба яки чанага ике яисә берничә ат җиккәндә уртада, уртага. *Сафа абыйның төпкә җиккән кара турысы, авызлыгын тешләп, муенын аккошныкыдай бөгеп китерде дә әй китте бермәлне бөтен гәүдәсен туптай сикертеп!* Г.Бәширов. *Ие, «мичәүгә җигелгән ат» – пар атның сыңары, төпкә җигелә яхшы ат, аның янына, бау белән генә тагылган, тартар-тартмас ялкауланып бара торганы «мичәүләнгәне» була.* Р.Батулла

2) *күч.* Төп көч буларак. *Гыйлаҗи сабан арты тоткан, Фазыйл белән мин төпкә, Гали очка җигелгән, Шаһбаз, нәкъ сабанчы малайлар кебек, көйләпкөйләп, «атлар» куа иде.* Г.Ибраһимов. *Мөнәвәрә төпкә җигелгән, аның ике ягында Зөбәйдә белән Зифа, яннан Кара Гобәйнең унсигез яшьлек кызы Асия атлый.* З.Зәйнуллин

**ТӨПКЕ** *с.* 1) Су, җир, берәр масса һ.б.ш.ның астында, тирәндә булган; төптәге, эчтәге, тирәндәге. *Җир кабыгының төпке катламнары*

2) Берәр нәрсәнең югары очына, өстенә каршы якта урнашкан, аның нигезгә якын башындагы, аскы. --- *мылтык атсын өчен, аның төпке өлешендәге махсус тишек турысына янып торган филтә якынлаштырганнар.* Р.Әхмәтьянов

3) Иҗтимагый тормышта, социаль иерархиядә аскы баскычларда булган, түбән катлауларга караган. *Революция адәмнәр тормышының иң төпке катлауларынача төшеп, гади вакытта күзгә күренмәгән потенциаль көчләрне тартып чыгарып, олуг көрәш мәйданына ыргыта.* Г.Нигъмәти

4) Ачыктан-ачык булмаган, башка кешеләр сизмәслек, тирәндәге, йөрәктәге, күңел түрендәге. --- *тик йөрәкнең әллә кайсы бер төпке катлавында --- сагынуга, кызгануга охшаган бер якынлык кына калды.* Г.Ибраһимов. *Алар кузгаталар күңелнең Иң төпке агымнарын.* Ә.Давыдов

5) Парлап яки тройкалап җиккән атның төпкә җигелгәне. *[Җәләш] җигүле көенчә --- төм кара ике ат алып кайтты. Моның төпкесе тирә-якта атаклы булган бер юрга иде.* Г.Ибраһимов. *Төпке ат – төпкә җигелгән ат.* А.Тимергалин

**ТӨПКЕЛ** *и.* 1) Чокыр төбе; җир өстенең бик тирән, батынкы җире. *Сусыл чирәм эзләп, көтүче малларны ерак болыннарга алып барган, караңгы төпкелләргә, тирән чокырларга алып төшкән, күккә ашкан тау түбәләренә куган.* Г.Гыйльманов. *Хәмит югалган*

*сарыгын чокыр төпкелендә тапты.* Казан утлары

2) Урманның, агачлыкның иң куе урыны, иң эчке, үтеп керергә кыен булган түре. *Билбавына балтасын кыстырган да чыгып киткән бу кара урманның «Шүрәле төпкеле» дигән җиренә.* Г.Гыйльманов. *Кара урманның кара төпкеле – Минем өчен алтын сарай ул. Шул төпкелнең тирән сазларында Кызыл утта күмер көйрәтәм.* Атака

3) Тирән суның төбе. *Иелде егет коега. Онытылды әйтер сүз: Тирән кое төпкелендә Кое суы түгел, Күз...* Л.Зөлкарнәй. *Нибары бер талпыну һәм бер, нибары бер адым: дәрья төпкеленә төшеп юк булган ташны гына күтәп торганнар диярсең, баягы дулкыннар чайкалудан туктады.* А.Әхмәтгалиева

4) *күч.* Провинция; мәдәният үзәгеннән, шәһәрләрдән ерак җир. *Аптырарлык та, Рәсәй төпкелендәге ташландык диярлек авылда чегән хатыны әллә кайдагы зәңгәр диңгезле Испания хакында: «Анда минем туган туфрак», – дип утырсын да...* К.Кара

5) *күч.* Җан, күңел, хәтер һ.б.ш.ның иң яшерен урыны. *Үз халкының онытылган гадәте җанының нindидер төпкелләреннән күтәрелде...* А.Хәлим. *Тонык кына иртә таңда күреп, Шундук онытылган төшләрем Төшендерде хәтер төпкелендә Әллә нинди серле төш барын.* З.Мансуров. *Матди яктан кысанрак чакта «Тәрҗеман»ның гомерен ялгаганмы ул, әллә башка бер сәбәптән тарих төпкеленә төшеп югалганмы?* Р.Хәмидуллина

**ТӨПКЕЛЛЕК** *и.* 1) Басу, урман һ.б.ш. урыннардагы уйсулык

2) Елга яки күл төбе, чоңгыл, бик тирән урын. *Малай төпкеллеккә эләккән*

**ТӨП КОДА** *и. этн. к.* **башкода**. *Төп кода – озын, җирән кеше – ир уртасы гына икән әле, күрәсең, беренче малаен гына өйләндерә торгандыр...* Ә.Еники. *Кызын бирүзе төп кода һәм төп кодагый буларак озата барырга тиешле Раһиба җиңги, олаудан калмыйм дигәндәй, йөгереп барып, арбасына утырды.* А.Хәлим

**ТӨПЛӘГЕЧ** *и.* **1.** *тех.* Агач, куак төпләрен тамырлары белән йолкып чыгара торган машина. *Урман чистартканда, төпләгечләрдән файдаланалар*

**2.** *с. мәгъ.* Төпли торган. *Төпләгеч аппарат*

**ТӨПЛӘМ** *и.* 1) Бер төпсәгә, бер төркемгә җыелган язмалар, документлар һ.б. *Кулларына яртышар капчык тулырлык кәгазь төпләме күтәргәннәр, күзләре төнге ябалакныкы шикелле ялт-йолт килеп тора.* В.Имамов

2) Кечерәк күләмле әдәби әсәрләр җыентыгы; том, җилд. *Шуннан соң шагыйрь --- «Персия мотивлары» лирик төпләмен [язды].* Х.Госман

3) Билгеле бер вакыт эчендә чыккан газет-журналларның төпләнгән җыелмасы; подшивка. *Мәскәү егете гәзит төпләмен япты, Фәсхетдин агайга сынаулы караш ташлады.* М.Мәһдиев

**ТӨПЛӘМӘ** *и. к.* **төпләм** (*3 мәгъ.*). *Тиз генә китапханәгә мендем дә «Вечёрка»ның төпләмәләрен актара башладым.* Р.Миңнуллин. *Тиз генә газета төпләмәләрен актарырга керештек һәм... таптык!* Мәгърифәт

**ТӨПЛӘНҮ** I *ф. төш. юн. к.* **төпләү** (*1–2 мәгъ.*). *Андагы шкафны, шкафтагы матур төпләнгән китапларны, стенага асылган путаллы рамлы картиналарны, зур язу өстәлен, йомшак диваннарны һәм идәнгә җәелгән хәтфә паласларны күреп, ул хәйран калды.* М.Гали. *Җитен тегәрҗеп белән төпләнгән, еш кына безнең милләтебездә яңгырлар астында саргайган төссез сары кәгазьгә басылган бу Китаптан никадәр гаярьлек, ышаныч һәм кодрәт актарып чыгара!..* А.Хәлим

**Төпләнә башлау** Төпләнергә тотыну

**Төпләнеп бетү** Төпләнү процессы тәмамлану. *Тиздән басылып чыгачак, ягъни төпләнеп бетәчәк, аннан сезгә җибәрермен.* Ш.Мөхәммәдев

**Төпләнеп тору** Даими рәвештә төпләнү, хәзерге вакытта төпләнү

**ТӨПЛӘНҮ** II *ф.* 1) Тамырлары белән туфракка берегү, тамыр җибәрү, тамырлану. *Имән каты җиргә төпләнер.* Мәкаль

2) Суганча, баш хасил итү

3) *күч.* Билгеле бер җирдә озаклап яисә бөтенләйгә яшәргә дип ныклап урнашу; җирләшү. *Шуңа күрә дә ир-егетләр ерак-еraклардан авылга ялгыз калган әнкәләре янына кайтып төпләнәләр.* Б.Камалов. *Йорт васыять ителгән дип, бу авылда кем төпләнә әле.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Урнашу, формалашу, ныгу. *Бу сүз көрәштерүләр, сүз югыннан сүз булсын, тел кычытканнан эш булсын, рәвешендә түгел, бәлки --- һәрбер кешенең җәмгыятьтә тоткан урынына карап, төпләнгән кискен карашларның утлар чыгару дәрәҗәсендә бер-беренә каты чарпышулар рәвешендә иде.* Ш.Камал. *Фәнни информациянең тизлек белән арта баруы галимне билгеле бер өлкәдә ныграк төпләнергә этәрә.* Н.Юзиев

5) *күч.* Акыл җыю. *Ирләр туа ике тапкыр: башта Кеше булып туа, төпләнә.* Д.Сирай

6) *күч.* Нинди дә булса вазифаны башкарырга ныклап урнашып калу, вазифаны озак еллар башкарырга алыну. *Әдәбиятта яшь талантларның юклыгы аларның барлыгын күрергә теләмәүдән дә һәм күрергә сәләтсез кешеләрнең редакцияләрдә төпләнеп утыруларыннан да килә, билгеле.* Ф.Яхин

**Төпләнә башлау** Төпләнүгә табан бару

**Төпләнә тору** Башкалардан алда төпләнү, берәр эш-хәлгә кадәр төпләнү. *--- моңарчы гел күченеп йөргән ырулар да әкренләп-әкренләп үз җирләрендә төпләнә тордылар: агачтан өйләр салып, иген игеп яши башладылар.* Н.Фәттах

**Төпләнә төшү** Ныграк төпләнү

**Төпләнеп алу** Тиз арада, ныклап төпләнү. *Аулакта, урмандагы өйдә төпләнеп алган.* М.Галиев. *Чарлак өйгә ут кебек сары чәчле, сипкелле бер инженер төпләнеп алды.* Т.Нурмөхәммәтов

**Төпләнеп йөрү** Төпләнү мәшәкатьләре белән мәшгуль булу

**Төпләнеп калу** Тулысынча төпләнү. *Никитин юл буена кайда туктарга, кайда төпләнеп калырга дип уйланып кайтты.* М.Галиев. *Туктагыз, әгъла бер үсемлек-нигъмәтнең чит-ят туфраклардан кызлар кебек утырма-кунакка гына килеп, шунда бөтенләйгә утырып төпләнеп калганы юкмыни?* А.Хәлим

**Төпләнеп килү** Акрынлап төпләнү, төпләнүгә табан бару

**Төпләнеп китү** Билгеле вакыттан алып төпләнү

**ТӨПЛӘП** I *рәв.* 1) Ныклап, җитди рәвештә, һәрьяклап. *Бүгенме, иртәгәме төпләп – актык тапкыр сөйләшергә кирәк.* Г.Ибраһимов. *Гомумән, ул – аз сүзле кеше, тигез, тыныч холыклы, сүз көрәштерергә, шаулап бәхәсләшергә яратмый, әмма инде сөйләргә туры килсә, бик төпләп, дәлилләп, сеңдерерлек итеп үзенекен әйтә дә белә.* Ә.Еники

2) Бөтенләйгә, даими рәвештә, ныклап; төпләнеп. *Назлы кунакларыбыз булып, шулай сагындырып килсәләр дә, сыерчыкларыбыз килгән көннәреннән, сәгатьләреннән үк төпләп урнашу ягын карыйлар.* А.Хәсәнов. *Ордер алып, бүлмәгә төпләп урнашканчы, тагын берничә көн узып китте.* Н.Фәттах

**ТӨПЛӘП** II *рәв.* Төбе белән, аерым төпләр рәвешендә. *Бакчадан төпләп кенә яшел суган йолкып чыкты, җилҗил килеп, келәткә кереп китте.* М.Хәсәнов. *Әйтик, Гәүһәрия апаны беләм, ул газетабызны җыеп туплап, төпләп тота. Аны күрше-күләнгә, туган-тумачага тарата.* И.Фәйзрахманов

**ТӨПЛӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **төпләү**. *Аларның күчермәләрен алып, китап итеп төпләттек.* Т.Нәҗмиев

**Төпләтә башлау** Төпләтергә керешү

**Төпләтеп алу** Тиз арада төпләтү. *Юлда солдат-мазар туктатса, шуны төпләтеп алдым, диярсең.* Г.Гобәй

**Төпләтеп кую** Мөмкинлек булганда, алдан ук төпләтү

**Төпләтеп тору** Даими рәвештә, әледән-әле төпләтү; хәзерге моментта төпләтү

**ТӨПЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Савыт-саба, кәрзин, чиләк һ.б.ш.га төп кую, төп беркетү, утырту. *Салкын тимерче, чиләк төпләгәндә, чүкече белән шулай дип әйтеп кагып эшли.* Н.Исәнбәт. *Техника беренче чиратта карауга мохтаҗ! Ул бит чиләк төпләү генә түгел.* Ә.Гаффар

2) Аяк киеменә ас салу, төп кую. *Конюх Галимҗан пима төпләп утыра иде.* Т.Таһиров. *Бу инде пима төпләргә, казанча әйтсәк, киез итеккә ас салырга өйрәнү.* М.Әмир

3) Китап, дәфтәр, журнал һ.б.ш. әйберләрне бер төпсәгә беркетеп тышлау. *[Габделҗаббар] йозак-ачкыч кебек нәрсәләрне төзәткән, китаплар төпләгән.* Х.Госман. *Фәүрия үзе китап төпләп мәшәкатьләнергә яратмый.* Ф.Яруллин

4) Агач яки куакны тамырлары белән йолкып алу; җирне берәр максат (чәчүлек, чабулык һ.б.) өчен агач, куак һәм түмгәкләрдән арындыру. *[Михай дәдәй:] Бездә бу турыда, атасы агач төпли, улы җир эшкәртә, оныгы иген игә, дигән әйтем дә бар.* М.Хәсәнов. *Каеннар – пар каеннар бар иде... Әллә күзләрем күрми, әллә төпләгәннәр...* А.Хәлим

5) Берәр нәрсәне ашап яки сарыф итеп бетерү. *Иртән, әле таң беленгәнче үк уяна, шешәне төпли дә чыгып ычкына бу.* Ф.Садриев

6) *күч.* Берәр эшне төгәлләү, тәмамлау, очына чыгу. *Сүзем төпләп шуны әйтәсем килә: җырчының музыка сәнгатенә куйган фидакарь хезмәте Тукай премиясе белән бәяләнергә тиеш, һәм ул аңа лаек дип саныйм мин.* М.Макаров

**Төпләп алу** Тиз арада төпләү. *Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә.* Ә.Еники

**Төпләп ату** Тиз генә, кызулык яки ачу белән төпләү; бөтенләйгә төпләү. *Кое янына килеп, куакларны тиз генә төпләп аттылар.* А.Тимергалин. *Рахманкуловның сул як күршеләре, бакча алган елны ук, каеннарының бер өлешен төпләп атып, түтәлләр ясап, яшелчә чәчтеләр.* М.Юныс

**Төпләп бару** Барсын да, берсен дә калдырмыйча төпләү. *Үзем булачак сүзлекнең аерым өземтәләрен «Казан утлары»нда күреп алганнан бирле җыйнап-төпләп бардым.* Р.Галләм

**Төпләп бетерү** Тәмам төпләү; төпләүне тәмамлау. *Аны тәмам төпләп бетергәнче, кыстašып, җитмеш җиденче мәртәбә урам әйләнгәннәр.* Ф.Яхин

**Төпләп бирү** Башка берәү өчен төпләү. *Аннан кемгә чалгы чарлаган, кемнең урагын тешәгән, чиләген төпләп биргән, чәй янында шул турыда сөйли иде.* Г.Гобәй. *Теге вакытны, ялгашымны төпләп бирә алмассыңмы, дип кергән идең.* Г.Галиев

**Төпләп карау** Булу-булмавын сынау өчен төпләү. *Әнвәрә, ияге белән генә ымлап, стенадагы теге алмагачка күрсәтте: – Шушыны төпләп кара әле син.* Ф.Садриев

**Төпләп кую** Алдан ук төпләү, тизтиз төпләү. *Ә мин инде анда эшне баштанаяк төпләп куйдым.* Г.Камал. *Аны тизрәк агачлык арасына кереп төпләп тә куйдылар.* К.Кара

**Төпләп ташлау** *к.* **төпләп ату**. *Менә ул хәзер йортыбызны бу зәһәр истән арындырды, өрәңгеләрне төпләп ташлады.* Т.Нурмөхәммәтов

**Төпләп тору** Даими рәвештә, әледән-әле яки хәзерге моментта төпләү

**Төпләп чыгу** Бөтенесен дә төпләү

**Төпләп ыргыту** *к.* **төпләп ату**. *Иң яхшысы: төпләп ыргытырга кул җитмәүдән генә утырган ике төп карт карлыганны алып атарга да шул тирәне чамаларга кирәк.* Н.Әхмәдиев. *Кемгәдер әрәмәләребез ошамады – аларны төпләп ыргыттык.* Ф.Яруллин

**Төпли башлау** Төпләргә тотыну. *Мич чыгарганга Пачарлардан да тиясе әле, пима да төпли башлады: кулы һөнәр белә, Аллага шөкер.* З.Зәйнуллин

**ТӨПЛӘ́Ү** II *и.* Урман булып үсеп утырган урынны агачлардан арындырып, җир ачып ашлык чәчелә торган басу; ышна. *Төпләвеңә тары чәч.* Мәкаль. *Пар алашаны кырдан алып кайттык та имәнлек буендагы төпләүгә сабан сөрергә киттек.* Безнең юл

**ТӨПЛӘҮЧЕ** *и.* Китап һ.б.ш. төпләү белән шөгыльләнүче, берәр нәрсәгә төп куючы оста. *Өченче көн авылга чиләк төпләүче бер кеше кереп кунган иде, шул сөйләгән икән.* Г.Гобәй

**ТӨПЛЕ** *с.* **1.** 1) Төбе бар, төп куелган; билгеле бер сыйфаттагы төбе булган. *– Яссы төпле кечерәк көймә ясарга, – дип тәкъдим итте Таймас, аптырашта калган малайларга карап.* А.Тимергалин. *Марҗа түтәй озын саплы зур чүмеч – аҗау белән чумырып ала да, күбекләндереп, тирән төпле тустаганга агыза.* Л.Зөлкарнәй

2) *күч.* Нигезле; дәлилле; эчтәлекле. *Революциядән соң, соңрак елларда,*

*аның иҗаты турында төплерәк һәм киңрәк тикшеренүләр Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри һәм Г.Халит иптәшләр тарафыннан ясалды.* М.Гали. *Әмма күңелдәге шикне хәл итәрлек төпле карашка килә алмады.* А.Шамов

3) *күч.* Җитди, ышанычлы; акыллы. *Юк, Дускаевны күпме генә «төпле егет» дип мактамасыннар, ул, Нургали, Шәйхи абзасы өйдә булса, мәктәпкә таба юл тотарга ашыкмаган булыр иде әле...* Ә.Еники. *Ахирәтләрем арасында Гөлсирә иң төплесе иде.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Җитдилеге, тирәнлеге, ныклыгы белән аерылып тора торган; җитди, тирән, нык. *Ш.Мәрҗани үзенең кыю һәм төпле фикерләре, тирән эчтәлекле әсәрләре белән танылгач та, Хөсәен хәзрәт башта аңа иярмәгән, дөресрәге, ияреpгә теләмәгән.* И.Нуруллин. *Укучыларның җаваплары кызык иде. Төпле иде.* Б.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Нигезләп, дәлилләп, тикшереп. *Бу эш планлы һәм төпле уйлап алып барылырга тиеш.* М.Җәлил. *Ләкин Газинурның үзгәрүе киемендә һәм йөзендә генә түгел, аның үзгәрүе күз карашында да, сүзләрне ашыкмыйча төпле итеп сөйләвендә дә, --- үзүзен тотуында да сизелә.* Г.Әпсәләмов

2) Җитди итеп, тирән итеп; акыл белән. *Дәрескә төпле әзерләнгән иде Мәрзия.* Ә.Моталлапов

**ТӨПЛЕК** I *с.* **1.** Олтанга, табанга яраклы; олтанга, табанга җитәрлек. *Бер төплек киез*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Олтан, табанлык. *Итек тектерергә төплек алдым. Төплек булдыру*

2) Берәр нәрсәне кертеп, кыстырып, утыртып кую өчен нигез, аслык. *– Чыршыны нык төплеккә һәм электр җылыткыч приборлардан кимендә бер метр ераклыкта куярга, – ди күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән инспекторы Әлмәрис Талипов.* Дуслык

**ТӨПЛЕК** II *и.* Кәүсәләрен кискәч, агачның төпләре генә утырып калган урын. *Каен җиләге үсә торган урыннар: ике нарат арасы, чыршылык, Галиулла чүнлеге, Торна елгасы, Зирексаз арты, Төплек, Пимәр каенлыгы --- һ.б.* М.Мәһдиев

**ТӨПЛЕКӘЙ** *и.* 1) Төче камырны сөткә, эремчеккә изеп пешерелгән калын табикмәк. *Милли ризыкларның ниндиләре генә юк: төплекәй, бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, тутырылган тавык.* М.Әмирханов

2) Төче камыр өстенә юка гына эремчек, төелгән бәрәңге катлавы җәеп пешерелгән пәрәмәч; шәңгә. *Аның сүзләрен куәтләгәндәй, Фәридәнең каенанасы Зәкия апа кордашларын нәкъ элеккечә мичтә кабарып пешкән төплекәй белән каршы алды.* Әгерҗе хәбәрләре

**ТӨПЛЕЛЕК** *и.* Төпле булу. *Фикернең төплелеге. Төплелеге күренеп тора*

**ТӨПМӘ** *рәв. диал.* Бөтенләй, һич тә, инде. *Төпмә булмаганны сөйләү*

**ТӨПСӘ** *и.* **1.** 1) Агачны кискәч яки сындыргач җирдә утырып калган өлеше; төп, түмгәк. *Җир астыннан Күл иясе чыга, төпсә артына кача.* Н.Фәттах. *Кая, ди, ул каеннар – төпсәләре дә эзсез югалган.* А.Хәлим. *Ай, кыралар урманны, нык кыралар: күпме тырпаешып утырган төпсә, егылган яки киселгән агач, тапап ыргытылган чыбык-чабык!* Ә.Әминев

2) *а.х.* Ашлык сабагының җитлекмәгән кыска төп өлеше; *русчасы:* **донце**

3) Поднос. *Ишектә кара киемле хезмәтче кыз күренде, аның кулында алтын төпсә, анда ризык, кувшин белән бер касә.* Р.Батулла

4) Китапның битләре тегелеп куелган урыны; тышкы ике каты капкачын берләштергән өлеше

5) *диал. к.* **төпчек** *(2 мәгъ. ). Мин монда тәмәке төпсәләреннән башка берни дә күрмим.* Ә.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тәбәнәк, юан, таза. *Тыгыз, төпсә гәүдәсе [егетнең] чыдам икәнен [күрсәтә].* Х.Госман

2) *диал.* Караңгы чырайлы, томса. *Дорфа, төпсә, тәрбиясез бит ул Сәйдәшләр оныгы.* Н.Гыйматдинова

**ТӨПСЕЗ** *с.* 1) Төбе булмаган; төбе төшкән, тишелгән яки ярылган. *Төпсез кисмәкне су белән тутырырга кушкан бит, юньсез хатын.* Д.Аппакова. *Кәртечкегә төшәлмәүнең тагын бер сәбәбе: кайбер малайга, өч-дүрт яшькә җитмичә, ыштан дигән нәрсәнең, эләксә дә, төпсезе генә.* З.Зәйнуллин

2) Гаять тирән, төбе күренмәслек. *Юлның уң ягында төпсез упкын, сул ягында күккә чаклы менгән вертикаль кыя.* И.Хуҗин. *Халидә ындыр артларында гына җәелеп яткан зәңгәр күл янына әкрен генә атлады. Шул төпсез күлгә карап утырырга ярата ул.* Х.Әбделмәнов

3) *күч.* Беркайчан да тулмый торган. *Игеннең бәрәкәте очты, амбарга кайтып җиткәнче үк, яртысы әллә кая китә башлады, колхоз келәтләре төпсез коега охшап калды.* Г.Бәширов. *Әмма бу байлык, әкренләп, мамык кебек, ил корытучыларның төпсез кесәсенә кереп тулмасмы?* И.Гази

4) *күч.* Беркайчан да саекмый, бетми торган. *Беренчедән, газ запаслары төпсез түгел.* Татарстан яшьләре. *Аның күңел дәрьясы чиксез, иҗат чишмәсе төпсез.* Безнең гәҗит

5) *күч.* Очсыз-кырыйсыз, иксез-чиксез. *Кичләрен йолдызлар сибелгән төпсез һәм серле күк йөзен күзәтү миңа да килешмидер, мөгаен.* Татарстан яшьләре. *Мөгаен, төпсез мәңгелек кенә шундый буладыр.* Безнең гәҗит

6) *күч.* Бетмәс-төкәнмәс, бетә торган түгел, бик зур, бик көчле. *Чорнаган төпсез тирән моңлык, тынычлык һәр ягын!* Н.Исәнбәт

7) *күч.* Нигезсез, дәлилсез; ышанычсыз. *Төпсез эш – төпсез чүмеч.* Мәкаль. *Бер караганда, бу фикер төпсез дә түгел кебек.* Г.Бәширов

8) *күч.* Мәгънәсез, уйланылмаган. *Үзенең бу кадәр төпсез җавап ишетәсен ул бер вакытта да уйлый алмаган иде.* Ф.Әмирхан. *Балаларга төпсез сүзләр сөйләп маташа.* Ш.Камал

9) *күч.* Җилкуар, җилбәзәк; төптән уйламый торган, мәнсез. *Төпсез кешедән төпсез сүз чыгар.* Мәкаль

◊ **Төпсез арбага утырту** Кемне дә булса бик авыр хәлгә кую, нык алдау. **Төпсез кәвешкә утырту** *к.* **төпсез арбага утырту**. **Төпсез кисмәккә су ташу** Мәгънәсез эш эшләү. **Төпсез кисмәккә су ташыту** Кешене азаплау өчен, аңардан юри һич төгәлләнми торган авыр эш эшләтү. *Үги анаң сиңа тикмәгә генә төпсез кисмәккә су ташытмаган.* Д.Аппакова. **Төпсез кое**

1) Беркайчан да кимеми, саекмый торган чыганак. *[Сәхипҗамал:] Хәтере төпсез кое шикелле. Кирәк икән, ул сиңа Такташның поэмаларын яттан укып бирә ала.* Н.Юзиев. *Баштарак җир астындагы нефть диңгезе бетмәс-төкәнмәс булып тоелса да, соңрак җир астының да төпсез кое түгеллеге беленде.* Ф.Яруллин; 2) Ахырына кадәр белеп бетереп булмый торган нәрсә. *Кеше күңеле – төпсез кое.* Мәкаль; 3) *к.* **төпсез мичкә**. *Авыл ул – «кара тишек», халык акчаларын йотып баручы төпсез кое, дигән хәтер калдыргыч сүзләрне еш ишетергә туры килә.* Татарстан яшьләре. **Төпсез коега төшерү** Кешене һәлакәткә юлыктыру, чарасыз хәлгә калдыру. --- *шактый булган бугай кәкре каенга терәтүләр, тик инде соңгысы аларның барысыннан да хәтәррәк килеп чыга: төпсез коега төртеп төшерә ул Сәләхетдинне...* К.Миңлебаев. **Төпсез коега төшү** Зур бәлагә тару, һәлакәткә юлыгу, чарасыз хәлгә калу. *Әйткән бер сүзгә ышансаң, төпсез коега төшәрсең.* Әйтем. **Төпсез көймәгә (кимәгә) утырту** *к.* **төпсез арбага утырту**. *Ул үзе бу мәсьәләдә безне төпсез көймәгә утыртмасын.* Ш.Камал. **Төпсез мичкә** Күп чыгым сорый торган эш; юкка-барга акча таратучы, акчаны саксыз тотучы. *Иң күп акча мәгариф системасына бирелде, диделәр. Әллә ничә миллиард сумнар турында сүз бара. Һич төпсез мичкә булды бу мәгариф!* Татарстан яшьләре. **Төпсез тагаракка утырту** *к.* **төпсез арбага утырту**. Алдап калдыру, буш калдыру. *Маһруй белән Гөлйөземне икебез икесен сугып алыйк та Сөнгать белән Гатауны төпсез тагаракка утыртыйк.* М.Фәйзи. **Төпсез тубал** 1) Туктаусыз чыгымнар сорый торган эш яисә кеше; туймас кеше; 2) Күп төпченә, күп сораша торган кеше. **Төпсез чанага утырту** *к.* **төпсез арбага утырту**. *Постта йоклап калып, иптәшләрен төпсез чанага ул утырткан.* М.Хөсни. *Бөтен Себер халкын төпсез чанага утыртып, юкка чыгуга дучар итүләре җитмәгән, күрәсең.* Ш.Алпар. **Төпсез чиләк** 1) *к.* **төпсез тубал**. *Күпме эчсәләр дә, туктый белмиләр, нәфесләре – төпсез чиләк.* Ватаным Татарстан; 2) Уйнашчы, азгын, бозык хатын. *Килдеңме, җир себеркесе, төпсез чиләк, азгын эт? Баланы алсаң да үкенечкә алырсың. Мулла абзый өч тапкыр өшкереп карады, булырлык түгел.* Н.Гыйматдинова. *Уйнашчы хатын кебек кабул иттеләр. «Төпсез чиләк» дигән кушамат ябышты.* Г.Гыйльманов. **Төпсез чуманга утырту** *к.* **төпсез арбага утырту**. *Хәзер кызыгызны бөтенләй үзебезгә иш булмаган халык җитәкләп китеп төпсез чуманга утыртырга торганын сизмисеңме?* М.Фәйзи. *Аңлаганыбызча, пайчыларны һәм эшчеләрне популяр әкияттәге кебек төпсез чуманга утыртып калдыруда төп гаеп атта, билгеле.* Туган як. **Төпсез ыштан** Артык юмарт, бер нәрсәсен дә кешедән кызганмый торган кеше турында

**ТӨПСЕЗ БӘЛЕШ** *и.* Табага турап салынган итле бәрәңге өстенә камыр җәймәсе каплап пешерелгән ашамлык. *[Сәхипҗамал:] Һәй юньсез, төпсез бәлешне кунакларга куялармыни?* А.Әхмәт

**ТӨПСЕ́З-КЫРЫЙСЫЗ** *с. диал. к.* **очсыз-кырыйсыз**. *Сулаган саен, йөрәге урыныннан куба, сулаган саен, үпкәләре ерткалана, күз алдына каралы-яшелле пәрдәләр корыла, үзе төпсез-кырыйсыз юклыкка китеп бара.* Ш.Камал

**ТӨПСЕЗЛЕК** *и.* 1) Иксез-чиксез, төбе булмаган урын; упкын. *Аның төпсезлегеннән боз салкыны күтәрелеп тәнне куырылдыра иде кебек.* М.Маликова. *Зәңгәрсу төпсезлек тирәнәйгәннән-тирәнәя, киңәйгәннән-киңәя.* Р.Батулла

2) *куч.* Принципсызлык. --- *үзенең гайбәтче карчык түгел икәнен аңламаенча, үзенең эшсезләрне юатыр өчен уенчык түгел икәнен аңламавы өчен гаепле, төпсезлектә, мәсләксезлектә гаепле.* Г.Исхакый

3) *куч.* Нигезсезлек, дәлилсезлек; рәтсезлек, өстән уйлау. --- *аларның чыгарган бу журналлары эчендә язылган мәкаләләренең мәгънәсезлеге, төпсезлеге өстенә гарәпчәдә неграмотный икәнлекләрен бик ачык күрсәтеп тора.* Г.Камал. *Аларның без һәммәсеннән дип әйтерлек шул соң дәрәҗәдә садәлек, җансызлык, төпсезлек, чуалчыклык күрәмез.* Җ.Вәлиди

**ТӨПСЕ́З-ЧИКСЕЗ** *с. сир.* Иге-чиге булмаган, бетмәс-төкәнмәс. *[Тукай] шигырь өчен төпсез-чиксез байлыкхәзинә булган табигатьтән, матурлыктан темалар эзләми.* Ш.Әхмәдиев

**ТӨПТӘ** *кер. сүз.* **1.** 1) Нигездә, асылда, беренче чиратта. *Галиәсгар ага – театр өлкәсендә, төптә, драматург, аннары инде артист булып та эшләп килгән кеше.* Безнең юл

2) Чынлыкта, чынында, дөреслектә, дөресен әйткәндә. *Дөресен генә әйткәндә, ул төптә усал малай түгел иде.* С.Җәлал. *Төптә, белем юк шул бездә.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ. диал.* Гомумән. *Аны монда сөйләп торуның, төптә, кирәге юк.* Ш.Камал

◊ **Төптә юкны сөйләү** Бөтенләй булмаганны сөйләү

**ТӨПТӘН** *рәв.* 1) Тирәнтен; җентекләп, игътибар белән. *Төптән уйлап карасаң, бу – халыкның ерак бабаларыбызны хөрмәт итүе, минемчә.* Ә.Галиев

2) Нигездән, тулысынча, җитди, кискен рәвештә. *Бу юлы мондагы вазгыять төптән үзгәргән иде: капитан бер читтә дер калтырап басып тора, аның урынында Сталин тирәсендә чуалган полковник утыра.* И.Хуҗин. *Монда нигездә төп ике мәсьәләне карадылар: сөтчелек тармагында технологияне төптән яңарту һәм авылда яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү.* Татарстан яшьләре

**ТӨ́П-ТӨП** *рәв.* 1) Бер урында берничә төп бергә. *Нечкә тирәкләр төп-төп укмашып, куе яшел яфракка күмелгәннәр.* Ш.Камал

2) Төпләре белән, берничә төп берьюлы

**ТӨПЧӘ** I *и. бот.* Суганчаның аскы өлешендә сабак белән тамырлар үсеп чыккан урын. *Әгәр суганчаны җиргә утыртсаң, төпчәдән аска таба чук тамыр системасы үсеп китә.* Биология

**ТӨПЧӘ** II *ы. к.* **түчә**. *Без абый белән, һәст, төпчә, дип кычкыра-кычкыра, ара-тирә сызгыргалап, чыбыркыларны шартлатып, көтүнең артыннан куып барабыз.* М.Гали

**ТӨПЧЕК** *и.* **1.** 1) Кечкенә төп, кечерәк агач төбе. *Аларны куакның иң төбеннән, төпчекләр калдырмыйча кисәләр, чөнки төпчекләргә корткычлар оялый.* Йорт эшләре

2) Нәрсәнең дә булса, гадәттә озынча әйбернең кечкенә калдыгы. *Аларда тузаннан каралып беткән шәм төпчекләре сакланып калган иде.* З.Фәткуллин. *Алар гел шулай, мыскыллап, я тәмәке төпчеге, я шешә бәреп китә.* Н.Гыйматдинова

3) Гаиләдә иң соң туган бала; кинҗә. *Менә төпчегең дә Газиз хәтле булып килә инде.* Г.Бәширов. *Рәхмәт инде, Миңсылу, үзең белән төпчегең-колынчагыңны да иярткәнсең.* А.Хәлим

4) *күч.* Нинди дә булса бер сыйныфның, катлауның калдыгы, калган бер вәкиле. *Горький әсәрләрендә тагын иске крепостной коллыгы заманы калдыгы – алпавыт, дворян сыйныфларыннан чыккан тормыш төпчекләрен дә очратабыз.* Г.Нигъмәти

**2.** *с. мәгъ.* 1) Гаиләдә иң соңыннан туган. *Заһидә туташ бу ишле гаиләдә төпчек кыз – тугызынчы бала булып дөньяга килә.* Р.Батулла. *Инде төпчек улы да үз юлын тапкач, җитмәсә, башлы-күзле дә булгач, әниләре Гөлҗәүһәр апаның күңеле тагын да түгәрәкләнгәндер.* Мәдәни җомга

2) *бот.* Гадәтидән кечерәк булган, зур яфрак янында үскән, өстәмә (үсемлек яфраклары тур). *Һәр катлаулы яфракның төбендә бер пар вак кына төпчек яфраклар була.* Ботаника

**ТӨПЧЕКЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **төпчену**

**Төпчекләп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле төпчекләү. *Әкрәм минем --- гади әйберләр турында төпчекләп торуымны яратмады.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Төпчекли башлау** Төпчекләргә тотыну

**ТӨПЧЕКЛЕК** *и.* Төпчек булу хәле. *Шул төпчеклек аркасындадыр инде, --- семьяда миңа башка балаларга тимәгән иркәләү тигән.* Ф.Хөсни

**ТӨПЧЕЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **төпчену**. *Берәр ятрак фикер искә килеп төшсә, мин аны бик саклык белән генә төпчеләп тикшердем.* Безнең юл

**Төпчеләп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле төпчеләү

**Төпчели башлау** Төпчеләргә тотыну

**ТӨПЧЕНҮ** *ф.* Нинди дә булса мәсьәлә, хәбәр, сүз һ.б.ш.ларның асылын белер өчен, бөтен ваклыкларны һәрьяклап тирәнтен тикшерү, каткат, бик җентекләп сорашу. *Бик күпне төпченергә яратучы түбән оч малайлары, иген урганда, сабанда йөргәндә, колхозның ындыр табакларында куна ятып печән чапкан вакытларда, Җәүдәтне сөйләтеп, бер нәрсәне беделәр ---.* З.Зәйнуллин. *Бу сүзләрнең төбендә ни ятканы, Фатих абыйның кемнәрдән зарлануы миңа билгеле түгел, төпченеп сораштыруы уңайсыз.* С.Сабиров

**Төпченә башлау** Төпченергә тотыну. *Язам, дисәм, язган әйберләреңне күрсәт, дип төпченә башлавыннан курыктым.* В.Нуруллин. *Аптыраганнан докторны тарткалый, төпченә башладык: «Ничек инде алай?»* Ф.Галиев

**Төпченә тору** Башка эш-хәрәкәт барышында төпченү; озаклап төпченү. *Төпченә торгач, берәр ай элек аларга «кунак абый» килгәнлеге ачыкланды.* А.Тимергалин

**Төпченә төшү** Тагын да төпченү

**Төпченеп алу** Бераз гына төпченү

**Төпченеп йөрү** Артыгын төпченү. *Ул чорда халык хәзерге шикелле түгел: һәрнәрсәдән закон таләп итеп, төпченеп йөрми, ни әйтсәң, шуңа риза, ни кушсаң – шуны эшли иде.* В.Нуруллин. *Закиров, авылга төшеп, минем кем белән һәмниләр сөйләшкәнемне төпченеп йөргән...* Татарстан яшьләре

**Төпченеп карау** Берәр нәтиҗәгә ирешү, сынау өчен төпченү. *Нурулла килененнән төпченеп караган иде, анысы: – Мин, каенатам, ирләр эшенә кысылмыйм ---, – диде.* Т.Гарипова

**Төпченеп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле, озаклап төпченү. *Кем син, төнгә каршы нишләп йөрисең, дип тә төпченеп тормады.* В.Нуруллин. *Мортазин моның Рәйсә ханым тарафыннан оештырылган эш икәнлеген аңлады да ныклап төпченеп тормады.* В.Имамов

**Төпченеп утыру** *к.* **төпченеп тору**. *Район газетасыннан да Рәхим атлы олы башлы корреспондент килеп, ярты көн төпченеп утырды.* Р.Вәлиев

**ТӨПЧЕНҮЛЕ** *с.* 1) Төпченергә теләгән, сынаулы. *Ләкин аның бу төпченүле карашы Газинурга ошап бетмәде.* Г.Әпсәләмов

2) Тәфсилле, җентекле, бәйнә-бәйнә. *Әлбәттә, Лирон Хәмидуллинның төпченүле эзләнүләреннән башка аның портреты тулы булмас иде.* З.Мансуров

**ТӨПЧЕНҮЧӘН** *с.* Төпченергә ярата торган, гел төпченә торган. *Әгәр дә безнең агаебыз сүзчәнрәк тә, төпченүчәнрәк тә кеше булса, бу чибәрне сайратып күп нәрсә белер иде.* Г.Бәширов. *Фёдор бик төпченүчән икән, чәй янында сугыш хәлләрен сораштырасораштыра аптыратып бетерде.* С.Сабиров

**ТӨПЧҮ** *ф.* 1) Үсемлек төбен тамыры белән казу; төпләү

2) Бик ваклап, җентекләп сораштыру яки аңлату. *Әхмәт аларны шулай ташлагач, артык төпчергә урын калмады.* Х.Кәрим. *«Акыллымы, бардыңмы, күрдеңме, исәнме ул, үзен ничек тоя, бер көйгәме?» – дип төпчеп сорашты.* Туган як

**Төпчеп бетерү** Тәмам, тоташ төпчү; нык төпчү. *...Актаралар журналларын – Абдуллиннар класс саен. Инде төпчеп бетерделәр Туган елын, туган аен.* М.Саттаров

**Төпчеп тору** Бертуктаусыз төпчү. *Габдулла аның хәлфә булуын берничек тә күз алдына китерә алмады, ләкин төпчеп тормады.* Ә.Фәйзи

**Төпчеп чыгу** Рәттән төпчү

**Төпчи башлау** Төпчергә керешү

**Төпчи төшү** Ныграк төпчү

**ТӨР** *и.* 1) Бериш әйберләрнең берберсеннән нинди дә булса сыйфаты, рәвеше, төзелеше, ясалышы һ.б.ш. белән бераз аерылып торганы; сорт, разряд. *Элек ул утын, бүрәнә, такта кебек тугыз төр әйбер сатса, хәзер фанера, паркет, көрәк, балта саплары, себерке, мунчала, кухня кирәк-ярагы, истәлек-бүләккә яраклы савыт-саба, ылыс оны – җәмгысы кырык төр әйбер тәкъдим итә.* Казан утлары. *Кайсы төрләрдә беренчелек өчен ярышачакбыз соң?* Сөембикә

2) Берәр классификациядә бертөрле, уртак билгеләргә ия булган предмет яки күренешләрне берләштергән һәм гомумирәк төркемнең – ыруның составына керә торган систематик берәмлек. *Шунда кемнең кайсы төр гаскәрдә хезмәт итәргә теләве белән дә кызыксындылар.* В.Нуруллин

3) Биологик классификациядә төп, иң әһәмиятле берәмлек – билгеле ареалда таралган, уртак токым үзенчәлекләре булган үсемлек яки хайваннар төркемен берләштергән тере организмнар группасы. *Амозонканың калын урманнарында яхе диган бер төр лиана үсә.* М.Мәһдиев. *Җир шарында тереклек формалары искиткеч күп: алты мең төр хайван һәм өч йөз мең төр үсемлек теркәлгән.* А.Тимергалин. *Бу төрләрнең кайберләреннән бәрәңгенең берничә мең культуралы сорты килеп чыккан.* Гомуми биология

4) *әд.* Нинди дә булса әдәбият яки сәнгать әсәрләренең үзенә генә хас сюжет, стилистика һ.б.ш. билгеләре белән аерылып торганы; жанр. *Әдәби иҗатның хәзерге дәвердә аерым мөһим булган төре – драматургия.* М.Җәлил. *Шуңа күрә дә бит халык әдәбиятының зур бер төре булган җырларда табигать картиналары бөтен терелеге, нечкәлекләре белән бирелгән.* Г.Нигъмәти

**ТӨ́РАРА** *с.* 1) *биол.* Үсемлек яисә хайваннарның ике яки берничә төре арасында бара торган; төрләр кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Үсемлекләрнең төрле төр вәкилләрен --- кушуны ерак төрләрне кушу, ягъни төрара гибридлаштыру дип атыйлар.* Гомуми биология. *Көньяк Америкада үсә торган төрара гибрид бәрәңгене гадәти төре белән кушылдыралар.* Ватаным Татарстан

2) Гомумән нәрсәнеңдер төрләренең үзара тәэсиренә караган; төрләр чигендә барлыкка килгән

**ТӨРӘН** *и.* Сабанның, суканың туфракны кисеп бара торган өлеше. *Күзен ачса... басып тора Бер зур карачкы, Төрән чаклы балта тоткан – Чын палачмыни.* Ф.Кәрим. *Малайларга кушылырга үзендә көч тә, гайрәт тә тапмаган Гапкадыйр бабай яңадан сабан төрәнен тукмарга тотынды.* З.Зәйнуллин

**ТӨРӘНЛЕ** *с.* Төрәне булган, төрән куелган. *Кама аръягының кара туфраклы төньяк районнарында, Зөя буйларында һәм Казан артының көньяк өлешендә, тирән сөрү өчен, каплаткыч төрәнле, кистергеч калагы булган сабаннар кулланылган.* Р.Фәхретдинов. *Ике төрәнле сабан белән җир сөрәләр.* Р.Батулла

**ТӨРӘ́Н САБАН** *и.* Борынгы кайтармасыз агач сука. *Каты чирәм --- тимер сабанны чыдатырлык түгел. --- [алар] әллә кайчаннан кузгалмый яткан төрән сабанны тартып чыгаралар.* Г.Ибраһимов

**ТӨРӘ́Н ТАКТАСЫ** *и.* Сабанның төрәне беркетелгән төп ягы. *Түбә астына төрән тактасы асылынган.* Ә.Моталлапов

**ТӨРБӘ** *и. гар.* Үлгән кешенең, гадәттә югары катламга караган, танылган шәхеснең кабере өстенә төзелгән корылма; мавзолей, тәкия. *Каберләре өстенә төрбә ясаттырам, яннарына чишмә казыттырам.* В.Имамов

**ТӨРГӘК** *и.* 1) Төргеч эченә төрелгән нәрсәләр, нәрсә дә булса төрелгән бәйләм. *Салон Болгарстан, Румыния илгизәрләре, бигрәк тә яшь хатын-кызлары белән тулы иде, аларның һәммәсе алагаем зур биштәрләрен, бүселгән төргәк-чемоданнарын, ыгы-зыгы килеп, автобусның багаж бүлегенә тутырды.* Т.Әйди

2) Исәпләү берәмлеге буларак бериш әйберләр бәйләме; пакет, рулон. *Сәдит пинжәк кесәләреннән бер төргәк гәзит кисемтәләрен чыгарып салды ---.* А.Хәлим. *Кичкырын ир төргәге белән ефәк бау кайтарып ташлады.* Н.Гыйматдинова

**ТӨРГӘКЛӘП** *рәв.* 1) Төргәк рәвешендә. *Кызлар яңадан киңәшеп алгач, төргәкләп бәйләнгән исле үләнне дә кулланырга булдылар.* Р.Сәгъди. *Кешеләр идән паласларын метрлап үлчәткәндә, ул төргәкләп ала.* Р.Нуртдинова

2) Төргәге, төргәкләре белән, тоташ килеш. *Бер төр телчеләр болай дип фараз итә: имеш, рус сәүдәгәрләре үз заманында базарларда күлмәк (сорочка) сатканда, аларны кырыгар данә итеп, төргәкләп сатканнар.* Г.Рәхим. *Төргәкләп аласыңмы, әллә берәмләпме – ихтыярың, рәхим ит.* Ватаным Татарстан

**ТӨРГӘКЛӘ́Ү** *ф.* Төргәк итеп бәйләү, төрү, төргәк рәвешенә китерү. *«Алан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять җитәкчелеге, авыл халкына җиңел булсын дип, күршеләрнең кырына төргәкли торган җайланмасы булган тракторын да, төйи торганын да җибәргән.* Н.Алан

**Төргәкләп бару** Һәммәсен дә берсе артыннан икенчесен төргәкләү

**Төргәкләп кую** Тиз арада төргәкләү; алдан ук төргәкләү хәстәрен күрү. *Арыш басуы күз алдында бушап кала, кырда калган саламны механизатор Владимир Семёнов тиз арада кыйммәтле азыкка әйләндереп төргәкләп куя.* Авыл таңнары

**Төргәкләп чыгу** Берәмтекләп, һәрберсен төргәкләү

**ТӨРГӘКЛЕ** *с.* Төргәккә төрелгән; төргәк рәвешендә бәйләнгән. *Шуны гына көтеп торган малай иплән кенә күлмәген, майкасын, бераз мыштырданып алгач, чалбарын салды, әнисе әзерләп биргән төргәктән сабынын чыгарды.* Ф.Латыйпов

**ТӨРГӘ́К-ТӨРГӘК** *с.* **1.** Төргәкләнгән, төргәкләргә төрелгән, төргәкләр белән исәпләнгән, төргәкләр рәвешендә булган. *Кулларын кесәләренә тыгып, җил сызгыртып кайтмадылар, төргәк-төргәк акча белән кайттылар.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Төргәкләп; төргәкләре белән, төргәкләр рәвешендә. *Тукымаларны төргәк-төргәк Кытайдан, Төркиядән алып кайтабыз.* Сәхнә. *Ул редакцияләргә төргәк-төргәк җибәрелә торган нәрсә дә түгел.* Ватаным Татарстан

**ТӨРГЕЧ** *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса төрер өчен кулланыла торган материал (тукыма, кәгазь һ.б.ш.). *Читтән килгән товарлар күз явын алырлык матур төргечләрдә булып, бәяләре дә тешли торган.* Казан утлары

2) Төрә торган җайланма, аппарат. *Печәнне рулонга төргеч һәм «Полесье» мал азыгы комбайны алганнар.* Кызыл таң

3) *бот.* Чәчәк яки җимешнең чәчәкләрен тышкы яктан төреп, саклап үсә торган тышкы яфрак. *Ләкин бакча петрушкасыннан аермалы буларак, чәчәкләренең гомуми төргеч яфраклары урынына чатырның үзеннән дә озынрак 2–3 асылма яфракчыклар үскән.* Ф.Закиров. *Тышкы яктан бу чәчәк төркеме төргеч дип йөртелә торган яшел яфраклар белән капланган.* Биология

**2.** *с. мәгъ.* Берәр нәрсәне төрә торган, төрү өчен хезмәт итә торган. *Бер ай элек кенә комбинат төргеч машина сатып алган, шуңа да бүген эшләр күпкә җиңеләйгән.* Кызыл таң

**ТӨРДӘШ** *и.* **1.** Бер үк төргә караган берәмлек. *Шунлыктан мәкаль астына аның миңа мәгълүм төрдәшләрен дә биргәләп бардым.* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* 1) Охшаш билгеләре белән бер төргә караган. *Төрдәш мәкальләрдә форма һәм эчтәлек ягыннан уртаклыклар булса да, мәгънә төсмерләнешендә бик әһәмиятле --- аермалар була.* Н.Исәнбәт

2) Үзара бәйле булган, бер-берсе белән бәйләнгән, катнашкан; чиктәш булган. --- *кайбер төрдәш белем бирү учреждениеләреннән аермалы буларак, биредә татар гимназиясен балалар белән тутыру проблемасы юк.* И.Фазлетдинов

**ТӨРДӘШЛЕК** *и.* Төрдәш булу сыйфаты. *Бу фигыль, --- үзенең төрдәшлегеннән файдаланып, тота да ияне алыштыра.* Н.Исәнбәт

**ТӨРЕК** *и.* 1) Төрки телләр семьясының угыз группасына караган телдә сөйләшә һәм башлыча Төркиядә яши торган халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Соңгы көннәрдә хуҗасын Казан урамнары буенча йөртүдән туеп беткән хезмәтче төрек атны туктатырга бик үк теләми иде, күрәсең.* К.Нәҗми. *А.Н. Самойлович 1923 елда гына «турки» һәм «турецкий» сүзләрен – бары төрекләрне һәм төрек телен атау өчен, «тюркские языки», «тюркские народы» тезмәләрен гомуми мәгънәдә куллана башлый.* М.Зәкиев

2) *иск.* Төрки халыкларның гомуми атамасы. *Радлов үзе төрек халыкларының фольклорын күбрәк күчмә тормышлы казакълардан эзләгән.* Н.Исәнбәт

◊ **Төрек малае** *иск.* Кызыл сургычлы, кызыл пичәтле аракы; кызылбаш, фәсле малай. *Әйдә, кем, кода, кодагыең бик әйбәт сарык итеннән аш пешереп калды, колхоз-район хәлләрен сөйләрсең, кешесенә күрә генә берәр төрек малае да табылыр ---.* М.Мәһдиев

**ТӨРЕ́К БОРЧАГЫ** *и. бот. к.* **ногыт борчагы**

**ТӨРЕКЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Төрекләр кебек. *Төрекләрчә әйтсәк, хөкүмәт «Алиның кәләпүшен Вәлигә, Вәлинекен Алига кидерергә» тырыша.* Ә.Ибраһим

**ТӨРЕКЛӘШТЕРҮ** *ф.* Төрек теле һәм төрек культурасы тәэсиренә дучар итү, шуны кертү. *Төркия турында сүз барганда, әлеге методның азчылык милләтләрне төрекләштерүгә хезмәт итүен дә истән чыгарырга ярамый.* Н.Фәттах. *Төрекчелек ул – барлык төркиләрне Төркия тирәсенә туплап, әкренләп төрекләштерү.* М.Зәкиев

**Төрекләштерә башлау** Төрекләштерергә керешү

**Төрекләштереп бару** Барысын да рәттән, туктаусыз, акрынлап төрекләштерү

**Төрекләштереп бетерү** Нык төрекләштерү, тулысынча төрекләштерү

**Төрекләштереп килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә, акрынлап төрекләштерү

**ТӨРЕКЛӘШҮ** *ф.* Ана телен, үзенең милли сыйфатларын югалтып, төрек телен һәм төрек культурасын кабул итү, төреккә әверелү. *Дөрес, аларның борынгы чорларда барлыкка килеп, соңыннан төрекләшкән булуы да ихтимал.* Н.Фәттах

**Төрекләшеп бару** Эзлекле рәвештә, акрынлап төрекләшү. *Соңгы санда икенче бер даими автор Айзат Шәймәрданов Төркиядә яшәүче татарларның төрекләшә баруын яза.* Р.Исхакый

**Төрекләшә башлау** Төрекләшүгә табан бару

**Төрекләшеп алу** Тиз арада төрекләшү

**Төрекләшеп бару** Акрын-акрын төрекләшү

**Төрекләшеп бетү** Тәмам төрекләшү

**ТӨРЕКЛЕК** *и.* 1) Төрек булу. *Безнең халыкның [бер ише]: --- «Без татар түгелмез», – дип, матбугатка чыгып кычкыралар, әллә нинди хыялый бер төреклек эзлиләр.* Җ.Вәлиди

2) *иск.* Төркилек. *Әмма ләкин төреклекнең ни икәнен аңламаган күпчелек янәшәсендә яшь, энергияле, милләтпәрвәр яңа бер буын җитлегеп килүен күрмәмешкә салынып булмый. Соңгылары төреклек галәмендә барган һәр вакыйганы бөтен вөҗданнары белән күзәтеп бара башладылар.* Казан утлары

**ТӨРЕКМӘН** *и.* Төрки телләр семьясының угыз группасына караган телдә сөйләшкән һәм Төрекмәнстанның төп халкын тәшкил иткән, шактый өлеше Үзбәкстан, Иран, Әфганстан һәм Таҗикстанда яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Төрекмәннәрнең килеп чыгышы турында сөйләгән риваятьләрдә Угыз ханның 24 улы булуы турында әйтелә.* Н.Фәттах

◊ **Төрекмән бабай** Татар мифологиясендә су иясе саналган рух

**ТӨРЕКМӘ́НЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Төрекмән телендә. --- *биредә [Төркиядә] укучы Татарстан һәм башка төрки дәүләтләрдән килгән студентлар Тукай шигырьләрен төрекчә, татарча, төрекмәнчә, башкортча укып күрсәттеләр.* И.Габидуллин. *Ул ярыйсы гына төрекмәнчә сукалый, ничек тә булса кешеләр белән аралаша, һәм, үзеңне ялгыз хис итмәс өчен, анысы да ярап тора.* Казан утлары

2) Төрекмән халкына хас булганча. *Төрекмәнчә бию. Төрекмәнчә киенү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төрекмән телендәге; төрекмән теленә хас. *Төрекмәнчә китап*

2) Төрекмән халкындагы, төрекмән халкына хас. *Төрекмәнчә музыка*

**ТӨРЕКМӘ́НЧӘЛӘП** *рәв. к.* **төрекмәнчә 1.** *– Эссе. Һич бер тәгамь йия алмадым, – дип төрекмәнчәләп әйткән булды [абый].* Х.Сарьян

**ТӨРЕК-ТАТАР** *җый. и.* 1) *иск.* Идел буенда яшәгән төркиләрнең, башлыча хәзерге татар халкын тәшкил иткән этник төркемнәрнең җыйма атамасы. *Төрек-татар халыклары бер ел эчендә, иң күбендә ике ел эчендә, яңалифкә күчеп бетәргә тиешләр.* Г.Гали. *Василий кенәз, төрек-татар халкын христиан итеп, ошбу төбәкләрдә тынычлык урнашыр дип уйлыймы?* М.Хәбибуллин

2) Госманлы төрекләре һәм хәзерге Төркия төрекләре белән татар халкының бәйләнешләренә караган күренешләр турында. *Шунда төрек-татар лицееен ачу өчен җан атып йөргән иде ул.* Ватаным Татарстан

**ТӨРЕ́КЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Төрек телендә. *Бакый ага Дәрдемәнд иҗатын бөтенләй яттан белә, Назыйм Хикмәтне төрекчә укый һәм хәзерге шагыйрьләр иҗаты белән таныш.* Г.Рәхим. *Һәрберсе үз телендә: кем төрекчә, кем русча, кем македонча яки, барысына да аңлашылсын дип, инглизчә аңлатса да, максат бер – төрле халыклар арасында бергә тыныч, тату яшәү юлларын эзләү.* Р.Хөснетдинов

2) Төрек халкына хас булганча. *– Төрекчә ясалган кофе, рәхим ит, ханым, – диде ул һәм, чынаяк куеп эчәр өчен, болдырдагы патефонны алып чыгарга ниятләп, эчкә керде.* Ә.Гаффар. *Ул диванда, аяк бөкләп, төрекчә утыра.* Идел

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төрек телендә язылган, төрек телендәге. *Хәзер үз китапханәмдә дә төрекчә китаплар байтак, Аллага шөкер.* Р.Батулла

2) Төрек халкына хас булган, төрек халкына караган. *Шуңа да күптәннән төрекчә музыкага җырлыйсым килеп йөрде.* Тамаша

**3.** *и. мәгъ.* Төрек теле. *Ул вакытта әле татар китап базарында театр китаплары юк дип әйтер дәрәҗәдә аз вә булганнарының зур кыйсьме төрекчәдән тәрҗемә вә яхут тәхриф уларак ясалган нәрсәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Әмма 1902–1903 елларда язган хатларының һәм әлеге дәфтәрендәге язмаларның төрекчәгә якын телдә язылганлыгын төрек әдәбияты тәэсире итеп карарга кирәк.* И.Нуруллин

**ТӨРЕ́КЧӘЛӘП** *рәв. к.* **төрекчә** (*1 мәгъ.*). *Бераздан алар янына станция жандармы килде һәм төрекчәләп нидер сорап куйды.* М.Галәү

**ТӨРЕ́КЧӘЛЕК** *и.* Төрек телендә, төрекчә булу. *Ләкин бу нәрсәгә «Йолдыз»ның төрекчәлек һәм «Тәрҗеман»чылык тенденцияләренең Г.Камалга булган вакытлы мәҗбүри йогынтысы гына дип карарга кирәк.* М.Гали

**ТӨРЕКЧЕ** *и. тар.* Төрекчелек тарафдары. *Күпчелек – буржуаз милләтче интеллигентлар, үзләрен төрекчеләр дип атап йөрүчеләр.* И.Рәми. *Үзе исламчы, төрекче булганга Төркиядә калып хезмәт итүне мәсләгенә каршы тапмый иде: татармы, гарәп яки фарсымы – аерып карамый, мөселман булгач, бар да бер.* Г.Ибраһимов

**ТӨРЕКЧЕЛЕК** *и.* Барлык төрки халыкларны Төркия, төрек теле, төрек мәдәнияте тирәсенә туплау һәм бер гомуми төрки телдә язуга күчү фикерен алга сөргән иҗтимагый агым. *Әдәби тел хәрәкәтендәге төп ике тенденция – татарчылык һәм төрекчелек – реакция елларында да кискен мәсьәләләрнең берсе булып калуын дәвам итте.* Г.Халит

**ТӨРЕЛӘ́-ТӨРЕЛӘ** *рәв. к.* **төрелеп**

**ТӨРЕЛЕП** *рәв.* Томырылып, йомылып. *Төрелеп-төрелеп килә чапкын атлар, чатный тезләр, тарта сеңерләр.* Н.Исәнбәт

**ТӨРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төрү**. *Самородок ак кәгазьгә төрелеп, аерым чехолга салынды һәм, бүтән токымнардан аерып, күн сумкага урнаштырылды.* Х.Камалов. *Корама юрганга төрелгән зур балчык чүлмәктә туптулы итле аш иде.* З.Зәйнуллин

2) *биол.* Йомылу, йомарлану, төргәк хасил итү, йомгак рәвешенә килү. *Бездә --- кәбестәләр иртәрәк төреләләр.* Г.Галиев

3) *күч.* Берәр нәрсә белән каплану, өретелү. *Күз төбеннән тиз генә борынын ала, Тын гына керфеккә ул төрелеп кала.* Ш.Бабич. *Сәед Яхъяның үз халкы азатлыгы өчен Король властена каршы алып барган тиңсез көрәше монда романтик пәрдәгә төрелеп, үрнәк төсендә сурәтләнә.* А.Әхмәдуллин

4) *күч. иск. Заман* һәм *җир* сүзләре белән килгәндә: «ара кыскару» мәгънәсен белдерә. *Заман төрелү – аз гына арада күп вакыт үтү*

**Төреләә бару** Берсе артыннан икенчесе төрелү, бер-бер артлы төрелү

**Төреләә башлау** Төрелергә тотыну

**Төрелеп бару** Төрелү алдында тору, төреләә башлау; төрелгән булу. *Ул тагы да матурайды, аның һәр хәрәкәте, кайда гына булмасын, үз-үзен тотуы, елмаеп сөйләшүләре илаһи бер гүзәллек белән төрелеп бара.* Г.Галиева

**Төрелеп бетү** Тәмам, ахыргача төрелү. *Елым төрелеп беткәч, Дәүләтгәрәй абзый абзар баганасындагы дүңгәләктән атның каеш тезгенен чишеп алды, тезген очын дуга башындагы божра аша үткәрде дә камыт бавына бәйләп куйды.* Н.Фәттах

**Төрелеп килү** Төрелү процессы башлану

**ТӨРЕМ** *с.* **1.** Төрү өчен хезмәт итә торган. *Ике кат сары төрем кәгазен сүтеп ташлаганнан соң, кәгазьләр эченнән фиолет төсендәге ефәк баш яулыгы [чыкты].* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ.* Бер мәртәбә төрү эше; бер мәртәбә төрерлек яки төрелгән нәрсә микъдары. *[Картның] гомерендә бер тамчы хәмер капканы, бер төрем тәмәке тартканы булмады.* В.Нуруллин

**ТӨРЕМЛЕК** *с.* Билгеле сандагы төремгә җитәрлек. *Алар миңа, надзиратель күрмәгәндә, бер паёк икмәк, өч-дүрт төремлек махорка бирделәр.* И.Салахов

**ТӨРЕНҖ** *и. фар. бот.* 1) Рутачалар семьялыгыннан көньякта үсә торган сары яки кызгылт сары төстәге калын кабыклы җимеш агачы; цитрон. *Елга буйларында мәңгеяшел төренҗләр үсә.* Физик география

2) Шул агачның әчкелтем тәмле, хуш исле җимеше

**ТӨРЕНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **төрү**. *Шинеленә төренеп, Шәрифҗан да чирәмгә сузылды.* И.Гази. *Шул чакта тыкрыктан кулына ак төенчек тоткан, жикет кигән, шәльяулыкка төренгән бер кыз килеп чыкты...* М.Мәһдиев

2) Чит-читләре бөтерелеп килү, куырылу. *Үләннәр төренде, кипте, саргайды.* Атака

3) *күч.* Берәр нәрсә белән каплану, өретелү. *Казан ягыннан килеп кергәндә үк, сине күккә үрләгән күп катлы йортлар каршылый, урамнар яшеллеккә төренгән.* И.Диндаров. *Бер офыктан икенче офыккача күкнең бите карачкылкүгелҗем пәрдәгә төренә.* Ә.Айдар

4) *күч.* Яшеренү. *[Ишан], диншәригать битлегенә төренеп, төрле кабахәтлекләр эшли.* М.Гали

**Төренә бару** Дәвамлы рәвештә төренү, торган саен ныграк төренү

**Төренә башлау** Төренергә тотыну

**Төренә төшү** Ныграк төренү

**Төренеп бару** *к.* **төренеп килү**. *Моңарчы караеп яткан җир дә акка төренеп бара.* Безнең гәҗит

**Төренеп бетү** Нык төренү. *Озын итәкле күлмәктән, тәмам диярлек төренеп беткән хәлендә, җилкәсе аша букча салган, култык астына мендәр кадәр төргәк кыстырган ул хатын Җабир агайга ни өчендер ышанычсыз кебек тоелып калды.* Ф.Яхин

**Төренеп йөрү** Һәрвакыт һәм һәр җирдә төренү. *Яулык, озын, калын күлмәкләр киеп төренеп йөрү гарәпләшү дип саналмыймы?* Безнең гәҗит

**Төренеп килү** Акрынлап төренә башлау. *Апрель азагы иде, бөтен дөнья яшеллеккә төренеп килгән чак иде, ачык тәрәзәдән бүлмәгә хуш ис тулган иде.* Ф.Садриев

**Төренеп тору** Даими рәвештә төренү; билгеле вакытка төренү

**Төренеп утыру** *сөйл. к.* **төренеп тору**. *Агачлар инде саргылт сагызлы яфракларга төренеп утыралар, юл буйларына яшь үлән түшәлә, анда беренче каз бәпкәләре дә күренә.* Ф.Садриев. *Багана утлары яктысында авыл урамнары әллә нинди сихри тынлыкка төренеп утыра.* А.Гыймадиев

**ТӨРЕПКӘ** *и. рус сөйл.* 1) Тәмәке кую өчен куышлыгы һәм авызга кабу өчен мөштеге булган тарту әсбабы. *Төрепкәсенә тыгыз итеп тәмәке тутыра да төннәр буе челем тартып яза да яза.* Р.Батулла. *Ә эш шунда: 1956 елга кадәр бу кул тәмәке тарта торган төрепкә тотып торган.* Мәдәни җомга

2) Телефон аппаратының бер ягы тыңлау, икенче ягы сөйләү өчен җайлаштырылган өлеше. *Аның формадан килмәскә искәртүеннән соң әйткән сүзләрен милициядә инде тыңламыйлар, телефон төрепкәсе сулкылдый иде.* М.Хуҗин. *Ә мин, шатлыгымнан шашардай булып: «Рәйхан, Рәйхан, кадерлем!» – дип, телефон төрепкәсе ярылырлык итеп кычкырам да кычкырам.* Р.Мулланурова

**ТӨРҖӘГУН** *и. гар.* 1) Күп кенә Коръән аятьләренең ахыргы – тәмамлап кую сүзе

2) *күч.* Берәр эш-вакыйганың ахыры, нәтиҗәсе. *Кисәктән менә сиңа «төрҗәгун»! Шулар вәкил, шулар без яраткан, без ышанган кешеләр!* Г.Тукай

◊ **Төрҗәгунга калу** Кичегү, иң соңгы чиккә кадәр сузылу

**ТӨРКЕ** *и.* Иске татар әдәби язма теле; Идел буе төрки халыкларының гомуми теле. *Укыдым гарәп – була яздым харап, укыдым фарсы – сафсата барсы, укыдым төрке – күңелемнең күрке.* Такмаза. *Мәгълүм ки, электә безнең әдәби телебез төрке дип аталган. (Игътибар итегез: төрки түгел, төрке).* Н.Исәнбәт

◊ **Төрке тану** Грамота белү, укый башлау. *Мәдрәсәләрдә, сабак абыстайларында хәреф танырга, укырга өйрәнүне «төркегә төшү», «төрке тану» дип йөрткәннәр, һәм бу уку программасы кызлар өчен Йосыф китабын көйләп укуга хәтле барып җиткән.* Н.Исәнбәт. *– Сездә бер дә кул куя торган кеше юкмыни? – Бер төрке таный торган кеше бар иде дә, ул читтә йөри.* Х.Садрый

**ТӨРКЕМ** *и.* 1) Бер урында җыелып торган кешеләр яки бергәрәк урнаштырылган әйберләр. *Бер – кулындагы хатына, бер – каршысында тыгыз төркем булып басып торган җитди чырайлы әбиләргә һәм апа-җиңгиләргә карый-карый, Гөлзәбәрнең Сталинградтан җибәргән соңгы хатын укый.* Г.Бәширов. *Әнә авыл башына, тимерче алачыгы янына, бер төркем халык җыелган.* А.Шамов

2) Нинди дә булса уртак үзенчәлекләре, охшашлыклары белән берләшә торган матдәләр, әйберләр, күренешләр җыелмасы. *Морфология фәнендә төп проблемаларның берсе – сүзләрне төркемнәргә аеру.* Татар грамматикасы

3) Эшләре, карашлары, максатлары бер булган иҗтимагый фикердәшләр берлеге. *Кыскасы, Г.Ибраһимовның бу дәвер әсәрләренә гомуми генә булса да күз салып тикшерү аларның кем каләме тарафыннан язылып, нинди иҗтимагый төркем карашын биргәнен күрсәтә ала.* Г.Нигъмәти

4) Берәр коллективның группа, бригада һ.б.ш.лар кебек аерым өлеше. *Яз көне Мирсәлим төркеме җирләрен чәчмәде.* Н.Гыйматдинова. *Сабый үзенең яшьтәшләре белән, чит-ят олы кешеләр белән аралаша белергә, төркемдә югалып калмаска тиеш.* Татарстан яшьләре

5) Көтү, өер. *Төн уздырыр өчен, чуртаннан куркып сайга чыккан ташбашлар төркеме, Идел читен вак кына дулкыннар белән бизәкләп, тирәнгәрәк китте.* М.Әмир

6) Гаскәри берлек; отряд. *Бурсык чокырына килеп җитеп, атларны яшергәч һәм кешеләрне урнаштыргач, озак та үтмәде, тегермән тавында бер төркем атлылар күренде.* И.Гази. *Ничек итеп разведкага баруыбыз, дошманның алдынгы төркеменә якын ук килеп һөҗүм ясавыбыз, икесен кулга төшерү, атышып чигенү күз алдыма килеп баса...* Ә.Айдар

7) Җинаятьчел максатлар белән берләшкән кешеләр бергәлеге; группировка. *Аннары төркем башлыгы – авторитет Валераны, муенына таш бәйләп, Зәңгәр күлгә ташладылар.* З.Мәхмүди

**ТӨРКЕМДӘШ** *и.* Бер төркемдә булган кемнәрнең яки нәрсәләрнең берсе. *Нәтиҗәдә, тулай торакның кызыл почмагында гына, төркемдәшләр арасында аларның туйлары була.* Мәгърифәт

**ТӨРКЕМЛӘНЕШ** *и.* Классификация, бүленеш; төркемләнү рәвеше, төркемләнү күренеше. *Мондый төркемләнештә сыйнфый-иҗтимагый темалар ачылмый кала, дип куркырга бер урын да юк.* Н.Исәнбәт

**ТӨРКЕМЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төркемләү**. *Җепселле композит материаллар төрлечә төркемләнә.* Төзү материаллары

2) Төркемнәр хасил итү. *Болар, атларын алдан җибәреп, үзләре аларның артларыннан төркемләнеп баралар.* Ф.Әмирхан. *Утрауларның күпчелеге архипелаглар булып төркемләнгән: мәсәлән, Яңа Зеландия, Гавай, Фиджи, Туамоту һ.б.* Материклар һәм океаннар географиясе

**Төркемләнә бару** Эзлекле рәвештә төркемләнү

**Төркемләнә башлау** Төркемләнергә тотыну

**Төркемләнә төшү** Бераз төркемләнгән кебек булу

**Төркемләнеп тору** Төркемнәр рәвешен алган булу. *Хәят җәһәт кенә адымнар белән олы юл өстендәге бер озын эскәмия янында төркемләнеп тора торган кунаклар янына килеп җитте.* Ф.Әмирхан

**ТӨРКЕМЛӘП** *рәв.* 1) Төркем булып, төркем хасил иткән хәлдә. *Төркемләп килгәннәре күбрәк, Петровск кебек калаларда ялланып, берәр җитәкче белән туп-туры билгеле берәр промыслога килеп төшәләр ---.* Ш.Камал. *Тамаша беткәч тә барлык башкаручылар, кайсылары төркемләп, кайсылары берәмберәм, караңгы төн яктырткычларыннан ераклашкан саен, төнге караңгыда эреп югала бардылар.* А.Нәҗми

2) Төркеме яки төркемнәре белән, төркем-төркем итеп. *Төркемләп озату*

**ТӨРКЕМЛӘ́П-ТӨРКЕМЛӘП** *рәв. к.* **төркем-төркем**. *Хәзер немецлар --- төркемләп-төркемләп әсирлеккә биреләләр.* Совет әдәбияты. *Ул арада егермеләп кеше гаҗәеп тизлек белән өскә үрмәләп менеп, төркемләп-төркемләп төрле якка китеп югалдылар.* И.Хуҗин

**ТӨРКЕМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Төркемнәргә аеру

2) Төркемләргә җыю, төркемгә берләштерү. *Трагедиядәге вакыйгаларны үзара охшашлыклары буенча төркемләгез.* Әдәбият

3) Классификацияләү, төрен-төргә аеру. *Сүзләрне төркемләгәндә, мәсәлән, беренче чиратта, аларның гомуми лексик мәгънәләре исәпкә алына ---.* Ф.Хисамова. *Гомумән, курку сәбәпләре күптөрле булып, аларны табигатькә, социаль чынбарлыкка, шәхеснең рухи дөньясына бәйләп тә төркемләргә була.* Шәһри Казан

**Төркемләп бару** Бер-бер артлы төркемләү

**Төркемләп бирү** Төркемләргә бүлешү

**Төркемләп кую** Төркемләү эшен алдан ук башкару

**Төркемләп тору** Даими рәвештә төркемләү

**Төркемләп чыгу** Рәттән төркемләү, һәммәсен төркемләү. *Башта геройларны төркемләп чыктым һәм алар арасында тискәреләренең өстенлек итүенә таң калдым!* Р.Рахман

**Төркемли башлау** Төркемләргә керешү

**ТӨРКЕМЛӘШҮ** *ф.* Төркемнәргә җыелу, оешу, туплану, төркем хасил итү. *Кешеләр, шул тирәгә төркемләшеп, әңгәмә коралар.* Ш.Маннур. *Бездән соң төркемләшеп бала-чагалар керде.* Н.Фәттах

**Төркемләшә башлау** Төркемләшергә тотыну

**Төркемләшеп алу** Тиз генә, кыска гына аралыкта төркемләшү

**Төркемләшеп бетү** Тәмам, тоташ, рәттән төркемләшү

**Төркемләшеп кую** Кинәт, көтмәгәндә төркемләшү; тиз арада төркемләшү

**Төркемләшеп тору** Туктаусыз төркемләшү, даими төркемләшү

**ТӨРКЕМЛЕ** *с.* Төркемгә тупланган, төркем хәлендәге, төркемнәргә аерылган. --- *Марат Парисович, ни өчен күп төркемле берничә этнос яшәгән төбәктә хөкүмәткә күпчелек башкортларны гына куясыз?* И.Сәетгалиев

**ТӨРКЕ́М-ТӨРКЕМ** *рәв.* **1.** Төркемнәр рәвешендә, төркемнәр булып, төркемләп. *Малайлар шактый урамнарны үтеп ярга җиткәндә, анда боз карарга килгән балалар, үсмерләр, зурлар төркем-төркем булып торалар иде инде.* Ә.Фәйзи. *Кая карама – төркем-төркем булып ашап-эчеп утыралар.* А.Фәлах

**2.** *с. мәгъ.* Аерым-аерым төркемнәрдән торган. *Ямьсез, канлы фаҗигаләр белән Төркем-төркем ачлар тарала.* М.Гафури. *Төркем-төркем казлар киләләр.* Ә.Еники

**ТӨРКЕМЧӘ** *и.* 1) Төркемнең бер өлеше; кечкенә төркем. *Бер үк сүз төркеменең төрле семантик төркемчәләрендә аерым грамматик категорияләр үзенчәлекле чагылыш табарга мөмкин.* Ф.Хисамова. *Исемлектә татарның нинди генә төрләре, төркемнәре һәм төркемчәләре юк!* Ватаным Татарстан

2) *биол.* Төрләр эчендәге кечерәк төркем; астөркем

**ТӨРКЕМЧӘЛӘ́Ү** *ф.* Төркемчәләргә аеру

**Төркемчәләп кую** Төркемчәләргә аеру эшен тәмамлау

**Төркемчәләп чыгу** Һәммәсен дә төркемчәләргә аеру

**ТӨРКЕМЧЕ** *и.* 1) *сир.* Төркемнәргә аерылу карашын яклаучы. *Тәнкыйтьчеләр мактамыйлар, Төркемчеләр якламыйлар.* Ш.Маннур

2) Җинаятьчел төркем әгъзасы. *Бүгенге төркемчеләр 1990 елларда булганнарыннан бик нык аерыла.* Безнең гәҗит

**ТӨРКЕМЧЕЛЕК** *и.* Бер коллектив, партия һ.б.ш. эчендә башкаларга каршы булган төркемнәр оешу яисә оештыру, берәр төркем эшчәнлегендә бердәмлек булмау, төркемнәргә аерылу, таркаулык күренеше. *Утызынчы елның башында әдәбият дөньясында шау-шу куптарган берничә язучы төркемчелектә гаепләнә.* Р.Батулла. *Анда ул партиянең Татарстан өлкә комитеты җитәкчелеген «артель» оештыруда, әшнәлектә, төркемчелектә һәм хәтта пантюркизмда гаепләп чыга.* Җ.Юныс

**ТӨРКЕТ** *и. төрки-монг.* Беренче һәм икенче төрки каганлык чорындагы борынгы төркиләрнең бер вәкиле. *Чал тарихка сөннәр-һуннар, эфталитлар, төркетләр, күк төрекләр, уйгурлар, гузлар, болгарлар, хәзәрләр, аварлар, бәҗәнәкләр, кыпчаклар һ.б. бик исемнәр белән кереп калганнар.* С.Шәмси

**ТӨРКИ** *с.* **1.** 1) Азия һәм Көнчыгыш Европада яшәгән, алтай семьясының бер группасын тәшкил иткән телләрдә сөйләшкән тугандаш халыкларны берләштергән этнос-тел бергәлегенә караган, шул халыкларныкы булган, шул халыкларның бергәлегенә мөнәсәбәтле. *Төрки телләрдә ясагычларга исемнәр һәм фигыльләр ясый торган кушымчалар керә.* Татар грамматикасы. *Хәер алга таба төрки театрлар ешрак – ел аралаш шушы фестивальдә очрашачак, дип куандырды.* Мәдәни җомга

2) Шул халыкларның барысы яки бер зур төркеме өчен уртак булган әдәби телгә караган, шул телдә язылган. *Бик ерак заманнарда Идел буеның төрки телле әдәбияты ничек шундый югары дәрәҗәгә күтәрелә алган соң?* Х.Госман

**2.** *и. мәгъ.* 1) Шул халыклар бергәлеге һәм аларның бер вәкиле. *Гомумән --- бу регионда борын-борыннан төркиләр һәм фин-угорлар яшәгән дип әйтә алабыз.* М.Зәкиев. *Уку-укытуда «ысулы саутия», ягъни аваз методы кертү эшен башлап җибәреп, Русия төркиләрен аң-белемле итүдә дә кискен борылыш ясаган ул.* Р.Хәмидуллина

2) Борынгырак чорда төрки халыкларның барысы, ә соңыннан зур бер төркеме өчен (Идел буенда яки Урта Азиядә яшәгән төркемнәр өчен) уртак булган әдәби тел; төрке. *Моголларның хәрби һәм оештыру терминнары барысы да төркинеке: уннар, йөзләргә бүлүдән башлап.* Татар милләт календаре

**ТӨРКИЛӘШТЕРҮ** *ф.* Төрки телләр һәм төрки культура тәэсиренә дучар итү; төрки итү, төркигә әйләндерү. *Хәзер төркиләр күпчелекне тәшкил итә торган кайбер регионнарда элек төркиләр, янәсе, бөтенләй булмаган, башка халыклар яшәгән; менә шул регионга кайдандыр (мәсәлән, Азиядән) төркиләр килеп кергән дә барлык башкаларны тиз генә төркиләштергәннәр.* М.Зәкиев

**Төркиләштерә башлау** Төркиләштерергә тотыну

**Төркиләштерә төшү** Бераз төркиләштерү; тагын да төркиләштерү

**Төркиләштереп бетерү** Тәмам төркиләштерү

**ТӨРКИЛӘШҮ** *ф.* Төрки булып китү; төрки тел, культура һ.б.ш.ларны тулысынча кабул итү, шулар тәэсиренә дучар булу. *Аларча, IX йөз башында Олы Венгрия иле көнбатышка күчеп китә, ә Идел-Уралда калганнары монда соңрак килгән төркиләр тәэсирендә төркиләшәләр һәм башкорт белән мишәрне формалаштыралар, янәсе.* М.Зәкиев

**Төркиләшә бару** Беразлап, тора-бара төркиләшү

**Төркиләшә башлау** Төркиләшүгә йөз тоту. *Безнең эра башларында бу сәүдәгә төркиләр кушылып, сугдиләр белән аралашып, катнашып киткәннәр, һәм V гасырга ул сугдиләр үзләре төркиләшә башлаганнар.* Фән һәм тел

**Төркиләшә төшү** Бераз төркиләшү; тагын да ныграк төркиләшү

**Төркиләшеп бару** Аз-азлап, акрынлап төркиләшү

**Төркиләшеп бетү** Тәмам төркиләшү. *Аларның бер өлеше тиздән туган якларына, гаиләләре янына кайтып киткән, икенчеләре исә, җирле кабиләләр белән кушылып, төркиләшеп беткәннәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**Төркиләшеп килү** Аз-азлап төркиләшү, үз уңае белән төркиләшү

**Төркиләшеп китү** Билгеле моменттан алып төркиләшү; күзгә күренеп төркиләшү. *...Шуңа күрә бик күп халыклар төрки телне җиңел генә кабул итеп төркиләшеп киткәннәр.* М.Зәкиев

**ТӨРКИЛЕК** *и.* Төрки булу сыйфаты; төрки халыкларга мөнәсәбәтлелек. *Төркилек дигән диңгез бар, шул диңгез үзләрен берләштереп торыр...* Р.Мөхәммәдиев. *Без хәзер скиф кабиләләрен төркилеге шик тудырмый торган кабиләләр белән тиңләү очракларына тукталыйк.* М.Зәкиев

**ТӨРКИ-ТАТАР** *и.* Изафәле тезмәдә килеп, «Идел буе төрки халыкларына караган» мәгънәсен белдерә торган сүз. *Казандагы дуслары үтенече белән аны Әстерхан төрки-татар хатын-кызларының «Сөембикә» берләшмәсе рәисе Наилә ханым каршыларга тиеш иде.* М.Әмирханов. *Ходайга мең шөкер, иске төрки-татар телен һәр мөселман белә, һәм барча яңа гамәл качак җәмгыятьләре өчен сөенеч кенә иде.* В.Имамов

**ТӨРКИ́ЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Төрки халыклардагыча. *Ел исәбе борынгы төркичә уникееллык циклда бирелә.* Т.Әйди

2) Төрки халыкларның берәр телендә. *Шул ук сөальне фарсыча, аннары төркичә кабатладылар.* З.Мурсиев

3) Идел буе төрки телендә, төркедә. *Шуңа карамастан XIX–XX йөздәге кайбер венгр тарихчылары «мажгар» сүзен венгрның үзатамасы булып киткән «мадьяр» этнонимына тиңләп, Идел-Уралдагы төркичә сөйләшә торган мажгарларны венгр дип, ягъни мадьяр дип игълан итәләр. Ләкин алар түбәндәге кире кагылмаслык тарихи фактларны исәпкә алып тормыйлар: беренчедән, мондагы мажгарлар бары төркичә сөйләшкән.* М.Зәкиев

**2.** *с. мәгъ.* Төрки телле; төркидә язылган. *Без исә бу китапта андагы күп кенә сүзләрне төркичә дип исбатларга тырыштык.* М.Зәкиев. *Саф төркичә атамалар: аргыр (айгыр) йолдызы – сириус; йап – кавәс йолдызлыгы; йәтикән – җидегән; куазый, оглак – җәди (кузый); учын – гакрәб; үкәк – бөреҗ ---.* Р.Әхмәтьянов

**ТӨРКИЧЕ** *и. тар.* Төркичелек яклы кеше, шул агымның тарафдары. *Насыйриның вафатыннан ун еллар үткәч, татар теле --- төрекчеләрне дә, төркичеләрне дә камил җиңде.* Г.Ибраһимов

**ТӨРКИЧЕЛЕК** *и.* 1) Барлык төрки халыкларны берләштерү, үстерү, ярдәмләшү максатын куйган иҗтимагый-сәяси агым. *Төркичелек – татар халкының меңнәрчә ел буе формалашкан тамыр системасы.* И.Әмирхан. *Ататөрек идарәсе дәверенә туры килгән бу чор Төркия тарихында төркичелек идеологиясенең җәелүе һәм үсеш алуы белән үзенчәлекле.* И.Рәмиева

2) Татар халкының әдәби теле итеп төрки телне алырга омтылыш; төрки телдә язу, төрки тел белән мавыгу. *Түркчелек термины бездә барлык төркиләрне атау өчен кабул ителгән «төрки» сүзеннән ясалырга һәм төркичелек формасында булырга тиеш иде ---.* М.Зәкиев

**ТӨРЛӘНДЕРГЕЧ** *с. лингв.* **1.** Сүзләрне төрләндерү өчен хезмәт итә торган. *Сүз ясалышы бүлегендә укучылар сүз төзелешен, сүзнең мәгънәле кисәкләрен, сүзьясагыч, төрьясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны да өйрәнәләр.* М.Шәкүрова. *Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. Боларны икенче төрле төрләндергеч кушымчалар дип тә атыйлар.* Татар грамматикасы

**2.** *и. мәгъ.* Сүзләрне төрләндерү өчен хезмәт итә торган чара. *Бу төркемнәрдәге сүзләр --- төрләндергечләр белән төрләнәләр.* Г.Алпаров

**ТӨРЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Төрле-төрле рәвешкә кертү, икенче төрлегә әйләндерү. *Ләкин бу әсәр бу вакыйгаларны заман һәм урында булган, күренеп үткән көенчә язмыйча, бәлки берсен алдан, икенчесен соңыннан китереп,*

*бер-беренә бутап, төрләндереп язуы мөмкин.* Г.Нигъмәти

2) Башка төре белән алмаштыру, икенче төргә үзгәртү, башкаландыру. *Башка вакытта, Мохтар белән Фәйзинең ял көннәрендә, Фәхри карчык ашны аз гына булса да төрләндерә.* Ш.Камал. *Ризыкны төрләндереп, кирәкле күләмдә салганда, аш та тәмле була.* З.Хәмидуллина

3) *лингв.* Сүзне төрле сан, зат, килеш, тартым һәм заман формаларына кую. *Өйгә эш: «чиләк» сүзен һәр ике санда төрләндереп дәфтәргә язып килергә...* М.Мәһдиев

4) *күч.* Берәр кеше турында төрле яктан сөйләү, яманатын сату; гайбәт сөйләү. *Дошманы белән хатынының да исемен янәшә куеп төрләндерәсе килсә дә, дөньясын шартлатырга җитәрлек микъдарда җыелган ачу төенчеген әлегә чишми, көчкә тыелып кала иде.* Н.Гыйматдинова

**Төрләндерә бару** Азлап-азлап төрләндерү. *Һәр яңа әсәрендә автор, үзәк кичереш хәрәкәтенә бәйле рәвештә, шигъри алымнарны яңарта, төрләндерә барып, шаблон трафаретлардан котылу юлларын эзли.* Т.Галиуллин

**Төрләндерә башлау** Төрләндерергә тотыну. *Ә моны элеп алдылар, бар җыелышларда төрләндерә башладылар.* Х.Камалов. *Сабантуйны гына алсак та, без бу бәйрәмне төрләндерә башладык.* Н.Алан

**Төрләндерә тору** Нәрсәдер башланганчы төрләндерү; әлегә төрләндерү

**Төрләндереп алу** Бераз гына төрләндерү. *Читкә чыгыбрак булса да, мин бу вакыйганы сөйлим әле: бер төрләндереп алу зарар итмәс ---.* Ә.Еники

**Төрләндереп бетерү** Нык төрләндерү; тулысынча, ахырына кадәр төрләндерү. *Нинди Лерадыр тагы, мулла барысына колакка ятышлы исемнәр кушкан, үзләре кырыкка төрләндереп бетерәләр.* К.Кара

**Төрләндереп җибәрү** Бераз төрләндерү. *Бу нәрсә концертны төрләндереп җибәрергә әйбәт булды.* Ф.Яруллин. *Тормышны төрләндереп җибәрсәң, яшәү күңеллерәк була, диләр.* Э.Яһудин

**Төрләндереп карау** Булу-булмавын сынау максаты белән төрләндерү. *Әлеге сүзләрдә, «а» хәрефеннән соң килгән хәрефне ачыклау өчен, ул сүзләрне төрләндереп карарга кирәк ---.* Фән һәм тел. *Табыннарны яшелчә һәм яшел тәмләткечләр белән төрләндереп карарга кирәк түгел микән?* Ирек мәйданы

**Төрләндереп тору** Даими рәвештә яки әледән-әле төрләндерү; хәзерге моментта төрләндерү. *Партадашың Гүзәл исә, киресенчә, коңгырт кара чәчләрен бер дә буямый, ә менә причёскаларны һәрвакыт төрләндереп тора.* Матур буласың килсә

**Төрләндереп чыгу** Башыннан ахырына кадәр төрләндерү; һәммәсен дә төрләндерү. *Семён Яковлевич, --- артык кыен булмаган сүзне әйтеп, шуны төрле килешләрдә төрләндереп чыгарга кушты.* Э.Касыймов

**ТӨРЛӘНЕШ** *и.* 1) Үзгәрү рәвеше, юлы, үзенчәлеге

2) Азмы-күпме аерылып торган төр; *к.* **вариант**. *Хәтта алардагы күп кенә мәкальләрнең сүзләрендә дә уртаклык булып, бары тик әйтелешләре яки аерым сүзләр төрләнешендә генә аерма була.* Н.Исәнбәт

3) *лингв.* Сүзләрнең төрле грамматик формалар алып үзгәрү күренеше. *Фигыльләр, заман һәм хәбәр төрлекләре белән төрләнешләрендә булган аерымлыкларына карап, безнең телебездә иң элгәре өч төркемчәгә бүленәләр.* Г.Алпаров. *Төрләнеш парадигмалары булган, ягъни өч затта берлектә һәм күплектә кулланылган фигыльләр затланышлы фигыльләр дип йөртелә ---.* Ф.Хисамова

**ТӨРЛӘНЕШЛЕ** *с. лингв.* Төрләнә торган, төрләнү парадигмасы булган. *Төрләнешле сүз төркемнәре*

**ТӨРЛӘНЕШСЕЗ** *с. лингв.* Төрләнми торган. *Төрләнешсез сүзләр*

**ТӨРЛӘНҮ** *ф.* 1) Төрле-төрле булып китү; төре күбәю; төрлеләнү

2) Төрле рәвешкә, кыяфәткә, шәкелгә керү, үзгәреп тору. *Әгәр дә ике ел гына элек бик җитди тоелган Сабираны һәм күбәләктәй очынган Кәримәне күреп калган кешеләр бүген аларның шушы сөйләшүләренә колак салсалар, кыз баланың егермегә кадәр кырыкка төрләнеп өлгерүенә хәйран булырлар иде.* Ф.Яхин. *Кешеләр кебек мәңге төрләнми чәчәкләр.* Мәдәни җомга

3) Башка төре белән алмашыну. *Кат-кат яулыгым, Катланадыр яулыгым, Түрәй агай килгәндә Төрләнәдер яулыгым.* Табышмак

4) *диал.* Авыруларның яисә йөкле хатыннарның берәр үзгәрәк ризык ашыйсылары килү, ашамлык талымлау

5) *лингв.* Исемнәр, алмашлыклар – сан, килеш һәм тартым, фигыльләр зат, сан һәм заман кушымчалары алып үзгәрү. *Русчада кушма саннарның барысы да килештә төрләнә икән.* М.Мәһдиев. *Кайбер хезмәтләрдә төрләнә торган сүз төркемнәре һәм төрләнми торган сүз төркемнәре дип икегә бүлү дә күзәтелә.* Татар грамматикасы

**Төрләнә бару** Аз-азлап төрләнү. *Һавада кошлар авазы төрләнә, ишәя бара.* Татарстан яшьләре

**Төрләнә башлау** Төрләнергә тотыну. *Мәсәлән, фигыль формаларыннан аерымланып (изоляцияләнеп) исемгә күчкән сүзләр гадәттә фигыльнең грамматик билгеләрен югалталар, исемнәр кебек төрләнә башлыйлар.* Ф.Хисамова

**Төрләнә бирү** Бернигә карамый төрләнү. *Аның яшьлек гүзәллеге, кара күзләре, алсу түгәрәк йөзе хәтеремдә сакланып, хыялда тагын да чибәррәк һәм күркәмрәк төсләрдә төрләнә бирде.* Ф.Яхин

**Төрләнеп бару** Торган саен тагын да төрләнү. *Һаҗәрнең көннән-көн күбәеп, төрләнеп барган теләкләре көнесәгате белән үтәлә бара.* Г.Ибраһимов

**Төрләнеп бетү** Тулысынча, ахырына кадәр төрләнү. *Дөрес, ул көннәрдән бирле кырыгы кырыкка төрләнеп беткәндер.* А.Хәсәнов

**Төрләнеп китү** Берәр хәлдән соң төрләнергә тотыну. *Әмма «егетләр»нең уе тәмам карурманга әверелгән, бәхәсләре төрләнеп киткән, Фәнзаман агада кайгылары юк иде.* Ф.Яхин. *Анда кайткач, ашау ягы да бераз төрләнеп китә бит инде: авызга кишер-кыяр ише нәрсә дә эләгә башлый.* М.Вәлиев

**Төрләнеп кую** Кинәт, көтмәгәндә төрләнү. *Дөрес, ристаннар тормышында да көннәр төрләнеп куя.* М.Әмирханов

**Төрләнеп җитү** Тәмам, ахырына кадәр төрләнү

**Төрләнеп тору** Даими рәвештә яки әледән-әле төрләнү; хәзерге моментта төрләнү. --- *федераль законнар бишектәге бала кебек бишкә төрләнеп тора ---.* Ватаным Татарстан

**ТӨРЛӘНЎ БӘЙРӘМЕ** *и. этн.* Раштуадан соң, киемне икенче ягы белән әйләндереп, хайван тиреләре һ.б.ш. нәрсәләр киеп, я битне яшереп, каплап урам буенча йөрү, өйдән өйгә кереп чыгу гадәте, керәшеннәрдә дини бәйрәм; нардуган; *русчасы:* **святки**

**ТӨРЛӘНҮЧӘН** *с.* 1) Үзгәрүчән, тотрыклы булмаган. *Гомер ул кырыкка төрләнүчән.* Ф.Яхин

2) Нәрсәнең дә булса үзенә ошаганын таләп итә торган; сайланучан (кеше тур.)

**ТӨРЛӘНҮЧӘНЛЕК** *и.* Төрләнүчән булу үзлеге

**ТӨРЛӘНЧЕК** *с.* Ризыкка карата бик таләпчән, төрләнүчән, сайланчык, талымсак

**ТӨРЛЕ** *с.* **1.** 1) Берничә төре булган; күп төрләрдән торган. *Хәзерге татар шигърияте, тормышның үзе шикелле, бай һәм төрле.* Т.Галиуллин

2) Аерым, башка. *Мине каравылчы Мирон чакырырга килгән иде, бардым, төрле авыллардан килгән крестьяннар егермеләп олауда, җәен кискән әрдәнәләрне төяп, урманнан чыгып киләләр.* Т.Гыйззәт

3) Һәркайсы үзенә генә хас үзенчәлекле, бер-беренә охшамаган, бер үк булмаган. *Чормасына төрле дару үсемлекләре – бәйләм-бәйләм аю әрем, юкә чәчәге, үги ана яфрагы, мәтрүшкә, ак чәчәк, яшь кычыткан һәм сирень чәчәкләре – кибәргә элеп куелган.* Г.Әпсәләмов. *Урманның кай төшендә нинди юл, нинди аланнар бар, нинди елгалар үтә – бөтенесе төрле төстәге сызыклар белән күрсәтелгән.* Г.Нәбиуллин

4) *сөйл.* Теләсә нинди, очраган бер. *Газинур, сиңа, бәлки, төрле сүз ишетерерләр.* Г.Әпсәләмов. *Колхозлар таралгач, җирләр кысыр кала, аны төрле чүп үләннәре баса.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кайбер кешеләр, кайсыберләр; аерым бер бергәлектән һәрбер кеше. *Аллабыз бит бер, Җамилә туташ, бер. Аллага ышанубыз гына төрлебезнеке төрледер.* М.Хәбибуллин. *Хезмәт срогын тутыргач, төрлебез төрле якка таралыштык.* Ф.Галиев

2) **төрлеләр** *күпл.* Җыелышның, утырышның көн тәртибендәге төп мәсьәләләрдән соң, гадәттә ахырдан карала торган пункт

◊ **Төрлесеннән катышкан** Никахсыз туган

**ТӨРЛЕК** *и. лингв. иск.* 1) *к.* **морфология**. *Г.Нугайбәк «Төрлек» грамматикасында (1911) бул- ярдәмче фигылен өйрәнүнең мөһим булуына игътибар итә һәм әлеге фигыль ярдәмендә ясалган заман формаларын күрсәтә.* Фән һәм тел

2) Сүз төрләндергеч кушымча. *Фигыльләр, заман һәм хәбәр төрлекләре белән төрләнешләрендә булган аерымлыкларына карап, безнең телебездә иң элгәре өч төркемчәгә бүленәләр.* Г.Алпаров

**ТӨРЛЕКСЕЗ** *с. сөйл.* Гел бер төрле, үзгәрешсез. *Гыйльман абзый безнең төрлексез авыл тормышына бераз гына булса да үзгәреш бирә.* Ак юл

**ТӨРЛЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Төрле-төрле итү, төрлелек кертү, төрлегә әйләндерү. --- *мөгаллимнәр иҗади эшли, белем һәм тәрбия бирүнең яңа алымнарыннан файдалана, гадәттәге методиканы баетырга, төрлеләндерергә, үтемлерәк итәргә, укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерергә омтыла.* И.Яруллин. *Сәнгатьтә яңа төр юнәлешләрне яулау безне төрлеләндерә генә.* Н.Алан

**Төрлеләндерә башлау** Төрлеләндерергә керешү

**Төрлеләндереп алу** Бераз төрлеләндерү

**Төрлеләндереп бару** Азлап-азлап төрлеләндерү

**Төрлеләндереп бетерү** Тәмам төрләндерү

**Төрлеләндереп җибәрү** Бераз төрлелек өстәү. --- *өстәмә тыныш билгеләр ярдәмендә әйтелгән мәгънәне яисә җиткерелгән хисне көчәйтеп, киңәйтеп, төрлеләндереп җибәрергә булыр иде.* Р.Харрасова. *Быел беренче тапкыр Саха Республикасының да катнашуы урыс Сабан туен тагын да ныграк төрлеләндереп җибәрде.* Мәдәни җомга

**Төрлеләндереп кую** Алдан ук төрлеләндерү

**Төрлеләндереп тору** Һәрдаим төрлеләндерү. *Моңа Рифатның кош азыгын төрлеләндереп, балanslап торуы да ярдәм итте.* Ә.Хәсәнов

**ТӨРЛЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Төрле-төрле булып китү; төрлегә әверелү. *Авылда тормыш шау-шуы, хезмәт музыкасы сүнмәде генә түгел, көчәйде, төрлеләнде.* Г.Гобәй. *Аның бу еллардагы иҗаты, тематика һәм жанр ягыннан тагын да төрлеләнеп, яңа сыйфатлары белән ачыла бара.* Әдипләребез

2) Үзгәрү, алмашынып тору

**Төрлеләнә башлау** Төрлеләнүгә табан бару

**Төрлеләнә төшү** Бераз төрлеләнү; тагын да ныграк төрлеләнү

**Төрлеләнеп бару** Акрынлап кына, аз-азлап төрлеләнү. *Бирелеш формалары да төрлеләнеп бара.* Казан утлары

**Төрлеләнеп бетү** Нык төрлеләнү

**Төрлеләнеп кую** Тик торганнан төрлеләнү

**Төрлеләнеп тору** Даими рәвештә төрлеләнү. *Аның һәрчак бизәлеп, төрлеләнеп торуы хозур.* Г.Хөсәенов. *Иммунологлар сүзләренә караганда, грипп – бик тә әшәке чир, ул ел саен төрлеләнеп тора, шуңа күрә вакцинаның да ел саен төрлесен чыгару таләп ителә.* Татарстан яшьләре

**ТӨРЛЕЛЕК** *и.* Рәвеше, сыйфаты, саны ягыннан күп төрле, һәртөрле, төрле-төрле булу. *Мәдәният һәм телләр төрлелеген саклау һәм җәмгыятьне, һәм тулаем кешелек дөньясын баетуның чын мәгънәсендә төп үсеш юнәлешенә әверелде.* Мәдәни җомга

**ТӨРЛЕ́-ТӨРЛЕ** *с.* Төрләре бик күп булган, һәртөрле; күп төрле. *Башында төрле-төрле уйлар, җаны борчулы.* Г.Әпсәләмов. *Концерт төрле-төрле интермедияләр, скетчлар, җырлар, биюләр белән аралашып барды.* Ә.Хәсәнов

**ТӨРЛЕ́ЧӘ** *рәв.* 1) Төрле рәвештә, төрле юл, төрле ысул белән. --- *әле өч-дүрт көн генә элек кече лейтенант погоннары таккан елгачылар исәнләшә*

*белмиләр: төрлесе төрле вакытта, төрлечә кычкыра иде.* М.Мәһдиев. *Чыннан да, тарих фәне төрле дәвердә төрлечә алып барылган сәясәткә буйсындырылды...* С.Алишев

2) Әле уңышлар белән, әле уңышсызлыклар белән; алай да, болай да; төрле хәлдә. *Хәлләр төрлечә инде*

**ТӨРМӘ** I *и.* Суд карары белән ирегеннән мәхрүм ителгән җинаятьчеләр һәм тикшерү астында булган кешеләр ябыла торган урын, бина, зиндан. *Патша төшү белән үк, аны, төрмәдән чыгарып, фронтка озатканнар икән.* К.Нәҗми. *Иптәшләрем белән бергә төрмә ишек алдыннан чыгып барганда, мин бик азга гына аның янында туктадым.* А.Шамов

**ТӨРМӘ** II *и. диал.* Киндер орлыгы һәм эремчек белән пешерелгән бөккән

**ТӨРМӘДӘШ** *и.* Кем белән дә булса бер үк төрмәдә утырган кеше. *Хәсән Туфанның бер төрмәдәш дусты Туфан хатынының кыюлыгына һәм тугрылыгына исе китә.* Татарстан яшьләре. *Аңлашыла ки, кышкы салкын көндә төрмәдәшләр өере юньле ният белән йөрми.* Мәдәни җомга

**ТӨРМӘЧЕ** *и.* 1) Төрмә аппаратында эшләүче; төрмә сакчысы. *[Тоткыннарның] берәрсе хәлдән таеп сыгылып төшсә, төрмәчеләр камерага кереп, аны бик каты кыйнап, кулларын күтәртеп, стена буенда сәгатьләр буе кузгалмый басып торырга мәҗбүр иткәннәр.* Г.Әпсәләмов

2) *сөйл.* Төрмәдә утыручы, мәхбүс; гомумән җинаятьче. *Шул рәвешле, кеше кыйнаучы төрмәче, һәрьяклы яклау табып, чынлыкта бернинди җәзасыз кала.* Безнең гәҗит

**ТӨРПӘ** *с. гар.* **1.** 1) Дорфа, төксе; сорауга тупас җавап бирә торган (кеше тур.). *Хәкимҗан агайга төрпәрәк бер караш ташлап, сүнгән трубкасын суырырга тотынды.* Э.Касыймов

2) Усал, чәнечкеле (сүз һ.б.ш. тур.). *Гыйльменисаның бу төрпә сүзләрендә ачыктан-ачык әйтелмәгән, шул ук вакытта әллә ни еракка да яшерелмәгән үпкә бар.* Ф.Хөсни

**2.** *рәв. мәгъ.* Дорфа, төксе рәвештә; кырыс. *Малай-шалай сораганда ул, мыегын да селкетмичә, төрпә генә кистереп әйтә.* Г.Бәширов. *– Я, авызыңдагы суыңны йот та әйтәсе сүзеңне әйтеп бетер, – дип, ихтыярсыз тагын бер мәртәбә төрпә генә чәнчеп алды.* С.Сабиров

◊ **Төрпә тору** Дорфа, тупас мөгамәлә күрсәтү

**ТӨРПӘЙТҮ** *ф. диал. к.* **тырпайту**. *[Мияубикә] йоннарын төрпәйтеп, күзләрен акайтып, балаларның өстенә ташлана.* М.Гафури. *Бигрәк тә тәрәзәнең бозылган бер күзеннән улап кергән җил тавышы белән бергә тоныкһәм тирәннән гөжләп килгән дулкын тавышлары аның эчен чымырдатып, чәчләрен төрпәйттерә иделәр.* Ш.Камал

**Төрпәйтеп куюТиз генә төрпәйтү**

**Төрпәйтеп тору** Туктаусыз төрпәйтү

**ТӨРПӘЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Төрпәгә, дорфага әверелү. *Бер минутта бөтенләй сүзсез калган, төрпәләнгән егетем, икенче минутта кинәт ачылып, эчендәгесен тышка селки башлый.* Ф.Хөсни

2) Тупас, дорфа кылану, үзен төрпә тоту

3) Мыскыллы, чәнечкеле, әшәке, тупас сүзләр әйтү; чәнчеп сөйләү. *[Җәмил] тик кенә йөрсә бер хәер иде әле, теленә салына, төрпәләнә, үчекли.* Б.Камалов

**ТӨРПӘЮ** *ф.* 1) Кабару, тырпаю. *Ул картинаны күз алдына китергән саен, чәчләрем төрпәя, тәннәрем чымырдап китә.* Ш.Камал

2) *күч.* Үпкәләү, турсаю, төрпәеп китү, дорфа кешегә әйләнү. *Төрпәгә ияргән төрпәйгән.* Мәкаль

**Төрпәеп калу** Берәр сәбәпле төрпәю

**Төрпәеп китү** Кинәт төрпәю

**ТӨРПЕ** *с. диал.* **1.** 1) Тырпаеп торган, чәнечкеле. *Төрпе кыл*

2) *күч.* Мәсхәрәле, чәнечкеле, кешенең хәтерен калдырырлык усал итеп әйтүчән. *[Кызның] төрпе теллелеге, төртеп-чәнчеп сөйләшүләре, үткен итеп шаярулары кимүен --- Зәйдүк тә чамалады.* Б.Камалов

3) *күч. диал.* Пешмәгән әйбер

**2.** *и. мәгъ.* Йон арасындагы каты кыл; каты төк. *Йонның төрпесе бар*

**3.** *рәв. мәгъ.* Артык тыйнак рәвештә; коры, кырыс итеп. *Чак кына борылып, күз кырые белән ничектер төрпе генә карап алды да, берни дә әйтмичә, камбузга кереп китте.* С.Сабиров

◊ **Төрпе тел** Дорфа, тупас кеше

**ТӨ́РРӘ** *ы.* Сарык куганда әйтелә. *Нәгъләт! Сыер булса – «һәш!» дияр идең, сарык булса – «төррә!» дип, эт булса – «чәбә!» дип, кәҗә булса – «кәҗә, ристан!» дип кычкырыр идең. Дуңгыз бит, чучка!* М.Әмир

**ТӨРТЕК** *и.* **1.** Нокта, төртке, кечкенә эз, билге

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нокта кебек кенә, кечкенә. *Тик аның нәзек, кыска булса да куллары, тәбәнәк, чатан булса да аяклары, төртек күзләре һәм зур, ачык авызы бар...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Үпкәчән, кешегә ачык булмаган, кинә саклаучан. *Төртек хатын*

3) *күч.* Чәнечкеле, төрткеле, усал (сүз һ.б.ш. тур.). *Кем беләндер яңа гына шушы хакта бәхәсләшкәннәр булса кирәк, югыйсә болай кинәт кенә әйтеп, төртек-төртек сораулар бирер идеме?* Ф.Яхин

**ТӨРТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төртү**

2) Хәрәкәт иткәндә берәр нәрсәгә барып терәлү, бәрелү, тию. *Аның битенбашын сөрткәләп, җәюле урынга салып чыкканда, ат, өй яныннан китеп, бакчаның капкасына борыны белән барып төртелгән иде.* Г.Ибраһимов. *--- һәм каток кырыендагы кар өеменә барып төртелә.* А.Шамов. *Шул арада аларның көймәләре ярга барып төртелде.* М.Гали

3) Туктау, терәлү, хәрәкәтсез калу, тоткарлану

4) Тырпаеп, беленеп, өскә чыгып тору. *Хәзерге монахларның йөзләрендә элекке кызыллык күренми, кабыргалары төртелеп тора.* К.Нәҗми

5) Тыгылу, бөялү. – *Льготалар кирәк түгел миңа, – дидем дә, тамак төбенә килеп төртелгән төерне көчкә тыеп, чыгып йөгердем.* Р.Вәлиев

6) Сөрлегү. *Бер адым атлаган идем, нәрсәгәдер аяк килеп төртелде.* Р.Сәгъди

7) *күч.* Көтмәгәндә берәр тоткарлыкка, комачауга юлыгу. *--- менә бу мәсьәләгә килгәндә инде, шагыйрь юлның бөтәшкән җиренә килеп төртелә.* Г.Нигъмәти

8) *куч.* Берәр нәрсәгә карау, төбәлү. *Түләк рамга бара да рәсемгә төртелә.* Н.Исәнбәт. *Морат алдында яткан, өстенә гөмбәз сурәте ясалган кәгазь кисәгенә төртелде.* М.Маликова

9) *куч.* Нык бирелү, игътибарны бер нәрсәгә юнәлдерү. *Өстенә пижама кигән Җәгъфәр күп вакытта китапларына төртелеп утыра.* Казан утлары

10) *куч.* Туры килү, очрау, тап булу. *Тик эчке карашым бушлыкка төртелде.* Ә.Гаффар

11) *куч.* Үтенеч белән мөрәҗәгать итү. *Кайсы йортка гына барып төртелсәк тә: «Үзебезгә тиешлесен без биреп җибәрдек инде, башкаларга кирәгез», – дип бирмиләр генә бит.* М.Гали. *Бел: синнән башка минем килеп төртелер кешем дә юк иде.* Ә.Еники

12) *куч.* Бер урыннан икенчесенә каңгырап аптырап яки эшсез кагылып-сугылып йөрү. *Бичаралар ары бәрелделәр, бире төртелделәр, гөнаһ шомлыгы, халык гаскәре җибәрми.* Г.Тукай

13) *куч.* Нindидер сәбәптән кинәт сөйләүдән, укудан тукталу. *Министр, кинәт кенә бугазына сөяк килеп тыгылган кеше сыман, төртелеп калды.* Х.Ибраһим. *Менә бит, шулай дидем дә төртелеп калдым.* Татар милләт календаре

14) *куч.* Сөйләгәндә, укыганда тотлыгу. --- *аның чыраенда кан әсәре калмаган кебек тоела, үзе ничектер төртелә-төртелә генә, авыр сөйләшә.* А.Тимергалин

15) *куч.* Нык сизелү, күзгә ташлану. *Җитдилеге күзгә төртелеп торганын күрми китү мөмкин түгел.* Г.Нигъмәти. *Бөтен өйдә күзгә төртелеп торган пөхтәлек.* Ак юл

16) *куч.* Кадалу, каты тию, чәнчү. *Сабакташының сүзләре күңеленә генә түгел, җанына ук төртелсә дә, хәтере калуын төсенә чыгармады Морза.* Ф.Баттал

**Төртелә төшү** Бераз төртелү

**Төртелә язу** Чак кына төртелми калу. *Карасак: дошманның тирә-якны күзәтеп торучы махсус стенасына барып төртелә язганбыз.* Өмет

**Төртелеп калу** Кисәк кенә төртелү. *Төшем килешенә килеп җиткәч, төртелеп калган, тик тора.* М.Мәһдиев. *Кече Сонга кадәр асфальт бар, өч чакрым калгач, төртелеп калды.* Н.Сафина

**Төртелеп китү** Узып барышлый төртелү. *Тавыш, ыгы-зыгы, чәбәләнү, күзе тонган сәфәрчеләр, талаш, кагылып, төртелеп китүләр, күзне тырный торган озын-озын чиратлар.* А.Гыйләҗев

**Төртелеп кую** Уйламаганда, кинәт төртелү

**Төртелеп тору** Гел, даими төртелү; билгеле вакыт төртелгән хәлдә калу. *Моның нәтиҗәләре шәһәрләр төзелешендә дә адым саен күзгә төртелеп тора: Ерак Себердән алып көньяк чикләргә кадәр һәркайда биналар бер калыптагы типовой проектлар буенча бастырып куела, архитекторларга талантларын ачарга мөмкинлек юк.* М.Маликова

**ТӨРТЕМ** *и.* 1) Төртү хәрәкәте; этеш. *Шунда айныгандай дерт итеп сискәнеп куюымы, әллә киң офыкларга таба ашкан юл күренешеме, башкасымы – Галимәнең тартылган күңел кылларына бушаныр өчен беренче төртем булдылар.* Ф.Яхин

2) Ачы итеп әйтелгән сүз, усал, төртмәле сүз. *Һәм шушы кечкенә генә төртем «хәтта татардан да яманрак» дигән төсмер китереп чыгара.* Идел

**ТӨРТЕМЕШ** *и. диал.* Караңгы чырайлы, аралашмаучан, аз сүзле кеше. *Төртемеш төртенчек төрткегә төртенә.* Р.Һади

**ТӨРТЕМЛЕ** *с. диал. к.* **төртмәле**. *[Вахитны] «Ул гына калыргамыни?», «Патша өйрәсен ул да бераз эчеп кайтсын!» дигән сыман төртемле сүзләр белән каршы алдылар.* М.Гафури

**ТӨРТЕНГӘН** *с. диал.* 1) Чукынган; христиан динендәге

2) Кире, тискәре; чикләнгән карашлы. *Аның [мөселман кешесенең] рухы азат, яшәеше ирекле булып калсын, ул тирә-якта гөрләп торган дөньяга кырын күз белән карауcы бер «төртенгән» кеше булмасын.* З.Мифтахов

**ТӨРТЕНДЕРҮ** *ф. сөйл.* 1) Чукындыру. *Тоя алса реаль дөньяны, Эгоистик «идеал» тәресенә Төртендерә ала кем аны, Кем?!* Х.Туфан

2) Хакимлектән бәреп төшерү. *Ә хәзер [патшаның] үзен төртендерделәр.* Ш.Маннур

**ТӨРТЕНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **төртү**. *Бермәлне, шунда төртенеп йөргәндә, бер төргәк китапка тап булдым.* Р.Миңнуллин

2) *сөйл.* Уң кул хәрәкәте белән тәре билгесен ясау; чукыну. *Картлач кардиналлар, епископлар, --- Укына-укына, карап төртенәләр Алтынланган тәреләренә.* М.Гафури. *Шәмси үлсә, ул да аңа, ягъни Шәмсигә, дога кылырга чиркәүгә бара. Аның рухына төртенә, аның котылуы өчен шәм куя...* Г.Исхакый

3) *гади с.* Киреләнү, үҗәтләнү. – *Кешеләр, сәламәтлек эзләп, кайлардан кадәрле киләләр, ә син ятасың шунда төртенеп, – ди.* Ф.Җамалетдинова

◊ **Төртенеп киткере** «Чукынып киткере, чукынгыры» мәгънәсендә тиргәү, каргау сүзе яки шаярту, үзалдыңа сүгенү сүзе. *Әхәт шаяртып кына котылмакчы булды: – Җырларым чабата кесәсендә калган бит, төртенеп киткере...* Г.Бәширов

**Төртенә башлау** Төртенергә тотыну. *Анна, кулын күтәреп, акыртын гына төртенә башлады.* Г.Исхакый

**Төртенеп алу** Тиз генә, бераз гына төртенү. *Шунысы кызык: камераларның кайда торганын да белеп бетергән үзе, камера каршысына килеп баса да, Алласын искә төшереп, төртенеп ала.* Татарстан яшьләре

**Төртенеп карау** Нәтиҗәсен белер өчен төртенү. *Аларга ияреп төртенеп карыйсы килә бит!* Р.Зәйдулла

**Төртенеп кую** Кисәк, бер мәртәбә төртенү

**Төртенеп тору** Даими рәвештә яки хәзерге моментта төртенү

**ТӨРТЕНЧЕК** *и. кимс.* Христиан диненә күчкән кеше. *Ах имансыз, төртенчек бер нәрсә икәнсең!* А.Расих

**ТӨРТЕШ** *и.* Орынган, кагылган сыман хәрәкәт. *Бу сиңа, беләсең килсә, кич белән капка төбендә, бер-береңнең кабыргасына төртеш, эһик-мөһик килү түгел, чын мәхәббәт диләр моны.* Г.Бәширов. *Әңгәмә буйдан-буйга ир белән хатынның бер-берсенә куллары белән төртеш, шаярып орыну белән аралашып барды.* Ә.Фәйзи

**ТӨРТКЕ** I *и.* 1) Нокта; очлы нәрсә белән төрткәннән соң кала торган нок-

та рәвешендәге билге. *[Сузыкларның] өсләренә калынлык, нечкәлекләр өчен сызыклар, тӧрткеләр ку[ела].* Г.Ибраһимов. *Икенче уку елында инде Рәкыйбә әби музыка серләренә тәмам төшенә башлаган һәм нота альбомындагы буйбуй юлларга карлыгачлар кебек тезелеп киткән төрткеләр аша көйне «күрә» белергә өйрәнеп килә иде.* М.Галиев

2) Бер генә төсле тукымада, тәндә икенче төстәге бөрчек, тап. *Тәнен кызгылт төрткеләр, тимгелләр басып алган сабый күз алдында сула, сүнә иде...* А.Хәлим. *Аның маңгаен һәм яңакларын зәңгәрсу төрткеләр һәм яра эзләре каплап алган.* Казан утлары

◊ **Төртке кебек** Бик кечкенә, бик вак

**ТӨРТКЕ** II *с. к.* **төртмәле**. *Гайнавал апасыннан ишеткән төртке сүзләр, әтисенең кызын яклап рәтле-башлы сүз әйтә алмавы --- йөрәкне талый торалар.* Х.Камалов. *Ә ул төртке сүзнең «тарихи» нигезе бар иде.* Ф.Сафиуллин

◊ **Төртке боткасы пешерү** Бертуктамый төртмәле сүзләр әйтеп тору

**ТӨРТКЕ** III *и. диал.* Өй кыегында ата һәм ана бәпкәләрнең түбәнге очлары тезелеп тора торган аркылы өрлек

**ТӨРТКЕЛЕ** *с.* 1) Үзендә төрткеләр, бөрчек-бөрчек кечкенә таплары булган. *Ике каш арасындагы кара төрткеле миңе белән бар тирә-якны яктыртып, бер апа килеп чыкты.* А.Хәлим

2) *күч.* Кинаяле, чәнечкеле, төртмәле. *Ачуланмый иде ул болай, сүзе генә төрткеле килеп чыкты.* Б.Камалов. *Юмор остасы Дамир Гыйсметдиннең сатирик хикәяләре, төрткеле шигырьләре «искермиләр», күгәрмиләр.* Мәгърифәт

**ТӨРТКЕ́-ТӨРТКЕ** *с.* Төрткеләр төшерелгән, төрткеләре булган. *Төрткетөртке тояк эзләре арасыннан, тасматасма булып, шулай ук көпчәк эзләре сузылган иде.* Н.Фәттах. *Гомәр Садриевич чүкеч, кечкенә балта сапларының җиренә җиткезеп шомартылган, төртке-төртке яндырып орнамент бизәкләр төшерелгән һәм үтәкүренмәле лак белән ялтыратылган булуына игътибар итте.* Казан утлары

**ТӨРТМӘ** *с.* **1.** Усал, кинаяле, чәнечкеле; зәһәр, әче. *Мин, боларның шундый зәһәрле сүзләрен, төртмә телләрен ишеткәч, түзә алмыйча, гарьләнеп кайтып киттем.* М.Гафури. *Төртмә телләләр күп уйланып тормый, төрлетөрле усал сүзләр ата.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Усал, зәһәр итеп. – *Нинди кунак? – диде Идрис төртмә генә.* Казан утлары

**3**. *и. мәгъ.* Кешенең күңеленә тидереп, төрттереп әйтелгән сүз. *Аның ачыктан-ачык ясалган төртмәсен дә үткәреп җибәрде Гәрәй.* А.Гыйләҗев

**ТӨРТМӘБИКӘ** *и. сөйл.* Усал, чәнечкеле сүзләр әйтүчән, әче телле хатын

**ТӨРТМӘКӘЙ** *с. сөйл.* 1) Төртмәле. *[Минҗан] төртмәкәй теллерәк булса да, сипкелле шофёр егеткә карап елмая иде.* М.Шәрифуллин. *Кәләшенең кеше яратуын, кеше дигәндә үлеп торуын, кем белән дә ачылып сөйләшүен, шаян холкын, төртмәкәйрәк телен өнәмәде.* Д.Булатова

2) *күч. диал.* Тискәре, үзсүзле

**ТӨРТМӘЛЕ** *с.* **1.** *к.* **төртмә 1.** – *Укытучы малайлары да көрәшәмени, – дигән төртмәле сүз белән каршы алды Рафаэльне Алмаз.* Р.Мөхәммәдиев. *Әй, андый төртмәле сүзләргә авыз турсайтмады хатын.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Усал, әче итеп. – *Нәрсәгә бик исәпкә баттың, Кәбиров, ә? – диде замполит төртмәле итеп.* Х.Камалов

**ТӨРТМЕШ** I *и.* 1) Кинаяләп әйтелә торган әче, зәһәр, чәнечкеле сүз. *[Дания:] Шәһәргә килмәм, дигән идең бит. [Зәйтүнә:] Апа, бу төртмешең миңа ябышмый. Бу юлы мин сиңа асрау булып килмәдем, --- укырга килдем.* Т.Гыйззәт

2) Усал холыклы, әче телле, караңгы чырайлы кеше. *Әче Бабайның: «Ах мәлгунь, ах төртмеш», – дип, аны орышканын --- яхшы хәтерлим, гәрчә ул чакта миңа әле өч яшь тә тулмаган булса да.* Татарстан яшьләре

**ТӨРТМЕШ** II *и. диал.* Сызык уены

**ТӨРТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **төртү**. *Белгәнебезчә, 1934 елда Гитлер хөкүмәт башына килгәч, коммунистларга террор уздыру нияте белән рейхстаг бинасына ут төрттерә, янгын чыгуны коммунистларга сылтый.* И.Салахов

2) Берәр авыр нәрсә белән төртү. *Бүрәнә белән төрттерү*

3) *сөйл.* Терәтеп, бик якын итеп, орындырып салу. *Мунчаны абзарга төрттереп салу*

4) *күч.* Усал кинаяләү, чәнчеп алу. *Бу сүзләрнең үзенә төрттереп әйтелүен председатель яхшы аңлый...* А.Әхмәт. *Телефон өзелгәч, Минзөфәр: «Узган елгы әкәмәтләреңне хатын әле дә төрттереп искә ала», – дип куйды.* Н.Хәсәнов

**Төрттерә башлау** Төрттерергә керешү. *Әмма үзенә төрттерә башласаң, һәркем кебек, бик өнәп бетерми.* Т.Нәҗмиев

**Төрттерә тору** Берәр эш-гамәлгә кадәр төрттерү; әледән-әле төрттерү. *Малай туса, ирләр борыннарын бер сырга югары күтәрә төшә, җае чыккан саен кызлы кешеләргә төрттерә тора: бел, янәсе, ул синең кебек брак ясаучы түгел, аныкы малай, малай!* Н.Әхмәдиев

**Төрттерә төшү** Бераз төрттерү; тагын да ныграк төрттерү

**Төрттерә язу** Чак төрттермичә калу

**Төрттереп алу** Тиз генә төрттерү; бераз төрттерү. *Бер күренгән чакта, Нәҗметдин аңа «үтилче» дип төрттереп алган иде, Касыйм ике-өч җөмлә белән аның авызына су каптырды ---.* В.Имамов

**Төрттереп җибәрү** Бераз төрттерү; кисәк төрттерү

**Төрттереп кую** Кисәк төрттерү; бер мәртәбә төрттерү. – *Анисы безгә караңгы, – дип, Тимеринең янтавына нык кына төрттереп куйды.* Г.Бәширов. – *Син, малай, сөйләгәндә, сүзеңне алай уйламыйча гына әйтеп ташларга ашыкма! – диде әтисе, Фәләхнең төрттереп куюын яратмыйча.* В.Нуруллин

**Төрттереп тору** Гел, даими рәвештә, әледән-әле яки хәзерге моментта төрттерү. *Җай чыккан саен, аның үзенә бәйләнеп, төрттереп торуның сәбәбен Илһам бик яхшы белә.* Ф.Садриев

**ТӨРТҮ** *ф.* 1) Очлы нәрсәнең очы белән нәрсәгә дә булса орыну, тидерү, җиңелчә кадап алу. *Нәгыйм имән бармагы белән үзенең күкрәгенә төртеп күрсәтте.* Ш.Камал. *Берсе кылыч кыны белән Илсөярнең җилкәсенә төртте.* Г.Гобәй

2) Берәр нәрсәне икенче бер нәрсәгә тидерү, терәү. *[Судан] чыгучылар, шәрә килеш кәкрәеп, комга борын төртә.* Ш.Рәкыйпов. *Елена ирнең йон баскан күкрәгенә борынын төртте ---.* М.Хәбибуллин. *Мирхас кыйнап ташланган кебек арыган иде ---, әз генә ятып алыйм дип баш төртүгә йоклап та китте.* Х.Камалов

3) Игътибарны берәр нәрсәгә юнәлтү яки ишарә итү өчен, аңа акрын гына кагылу. *Хәят акрын гына Әминәнең ботына төртте дә, мәгънәле генә көлемсерәп, аның күзләренә карады.* Ф.Әмирхан. *– Кара әле, безнең арттан кемдер йөгерә, – диде Салават, Хәлимгә терсәге белән төртеп.* А.Шамов

4) Кемне яки нәрсәне дә булса этәрү. *Бер-бер якка төртеп төшерәләр аны.* Т.Нәҗмиев. *Бульдозерлар көчле. Төртә, ишә. Тигезли дә куя. Эш бетә...* Р.Фәйзуллин. *Алары да иске: төртсәң, таралырга тора...* А.Хәлим

5) Сугу, бәрү. *Күбесе шаккаткан, кычкырганны, аякка сукканны түгел, кулдан тотып аркадан төртеп җибәргәнне дә сизмиләр.* М.Гали. *Башын игәч, иягенә төртеп, башын турайттылар.* М.Гафури

6) Бер урыннан икенче урынга күчерү. *Бер кырыйга төртү*

7) Берәр нәрсәнең эчендә сизелеп тору, этәреп аны кабарту, күпертү, тырпайту. *Күреп алдым: төендә ике каравай башларын як-якка төртеп яталар.* Н.Дәүли

8) Үсеп чыга башлау (мыек яки сакал төкләре тур.). *Шул борын астында сирәк төрткән кара төкләр күреп, Мортазин бер мәлгә әсәренеп куйды.* В.Имамов. *Әле яңа мыек төрткән, кавырсыннары да катып җитмәгән яшь-җилкенчәкләргә, малай-егетләргә алар җитәкче булды.* Ф.Латыйпов

9) Берәр нәрсәнең орлыгын чәчү яки үсентесен утырту. *Бакча артларында шаярып кына төртеп чыккан кыярлар ашап бетерә алмаслык булды.* М.Шәрифуллин. --- *Оя саен берәмлекләп орлыгын төртеп, кыскасы, билне бөгеп, җиде кат тир агызып утыртырга туры килде кукурузны ул елда.* Р.Төхфәтуллин

10) Берәр кеше яки җанлы-җансыз нәрсә торган якка таба хәрәкәт ясау, ымлау, күрсәтү. *Одеколон, сабын, теш щёткасы, паста кебек әйберләрне бармак төртеп күрсәтеп кенә җыялар.* Т.Нәҗмиев. --- *Һавадагы Киек Каз Юлына төртеп, кенәз сәер риваять сөйләп бирде.* В.Имамов

11) Берәр әйбер өслегенә тап, нокта, бөрчек һ.б.ш. кебек түгәрәк нәрсә кую, төшерү. *Хәниф абый кулына карандаш алып [нокталарны, өтерләрне] язып күрсәтте. --- Карандаш очы белән бер төртәсе дә бер бөтереп кенә аласы [икән].* Н.Дәүли

12) Кабызу, яндыру, үрләтү (ут тур.). *Күз иярмәс чая тизлек белән Бер насосны сөйрәп китереп, Ут төрттеләр Бензин сиптереп.* Х.Туфан. *Күңел уты, өмет уты учактагы ут түгел, бер шырпы төртеп кенә кабызып булмый.* Ф.Яруллин

13) *сөйл.* Берәр нәрсәне күрсәтү өчен, кискен хәрәкәт белән кемнең дә булса йөзенә бик якын китерү. *Гранатаны маңгаена төрткәч, Немец миңа үзе бәрелде.* Ф.Кәрим

14) *сөйл.* Эшне икенче берәүгә тәкәллефсез генә тапшыру. --- *КПСС өлкә комитеты 1985 елның ямьле май аенда Татарстанда үтә торган Чуваш әдәбияты һәм сәнгате атналыгында катнашучыларны Сабага төртте.* Т.Нәҗмиев

15) *сөйл.* Кемгә дә булса берәр нәрсәне тәкәллефсез, ашыгыч яки яшереп кенә бирү. *Ул үз өлешенең дә яртысын Маратның учына төртте һәм энесен ике куллап кочып алды.* Г.Гобәй. *Казан янындагы дачаларның берсендә акылы алтын бер кемсә хуҗа кешегә юк кына бәягә машинасы белән тирес төртмәкче икән.* Р.Гаффар

16) Яфрак яра, чәчәк ата башлау. *Җирнең өсте әле карлардан Яңа гына беткән ачылып, Яфракларын җылы мамыклардан Яңа гына төрткән талчыбык.* Ә.Исхак

17) *күч.* Шыту, туфракны тишеп чыгу (үсемлекләр тур.). *Ә [орлык] бер төртеп чыккач, кояш нурларына тотынып үсә, ныгый, шәбәя.* Ф.Яруллин

18) *күч.* Берәр якка юнәлдерү, төбәү. *Теге кеше, бичара, бернәрсә белмичә, башын җиргә төртеп, әкрен генә килә.* И.Гази

19) *күч.* Күңелгә ятышсыз, авыр, кинаяле сүз әйтү. *Миңнур картка аның болай да тырпаюы көчле иде, шуның өстенә аның да төртеп әйтергә теләве (ул шулай дип уйлады) аны урыныннан сикереп торырга мәҗбүр итте.* А.Шамов

20) *күч.* Берәр нәрсә турында язып кую, берәр фикерне кәгазьгә төшерү. *Хәреф төртсәң, шигырь үсеп чыгар – Шундый чагы әле җанымның...* Зөлфәт

21) *күч.* Кемгә дә булса ришвәт бирү. *Акча төрткәч, докторың эреде.* Г.Камал. *Кыз саклаган карчыкларга җәмгысына бер-ике тиен төртсәң, кызларның бөтенесе безнең кулда.* М.Фәйзи. *– Мә, садакадан булыр, ал, – диде ясавыл, йөзбашка бер алтын төртеп.* М.Хәбибуллин

◊ **Төртеп җибәрү** Кемгә дә булса төксе, кырыс мөнәсәбәт күрсәтү. *Әгәр син аны шулай төртеп җибәрсәң, үзеңнән ераклаштырырга сәбәп булырсың.* Г.Тукай. **Төртеп күрсәтү** Берәр нәрсәгә кемнең дә булса игътибарын гадәттә бик тупас рәвештә җәлеп итү. *Хәзер бу икәү процессуаль хаталарга гына төртеп күрсәтә алачак.* Өмет. **Төртеп төшерү** *к.* **төртеп чыгару**. **Төртеп үсү** Калышмыйча, артыннан басып, куып үсү. *[Зәйтүнә] сеңлесенең аны төртеп үсеп килгәнлеген искә ала.* Ф.Хөсни. **Төртеп чыгару** Кемне дә булса эшеннән, урыныннан куу, кысрыклап чыгару. **Төртсәң ишелергә тора** Бик иске, җимерелер хәлгә җиткән (йорт-җир тур.). *Чыннан да, биредә бер генә дә төзек йорт күзгә чалынмады диярлек, барысы да иске, төртсәң ишелергә тора шикелле.* М.Галәү

**Төртә бару** Рәттән барысын яки барысына төртү; акрынлап төртү. *Кар өемнәреннән койма буйларының арчылуы, бакчаларның кабарынып ачылуы һәм бераз яфрак төртә барган агачларның яз башына хас табигать шәрәлеген каплап бетерергә өлгермәве дә бу кыргыйлыкны арттыра иделәр булса кирәк.* Ф.Яхин

**Төртә башлау** Төртергә тотыну. *Егетнең уй-ниятен аңлап алган Ка-*

*сыйм, факелны алып, сүз әйтмәстән, өй эченә ут төртә башлады.* И.Хуҗин

**Төртеп алу** Тиз генә төртү. *Газинур терсәге белән Буранбайга төртеп алды.* Г.Бәширов. *[Ул] аннан соң кинәт кенә иптәшенә төртеп алды.* Н.Дәүли. *Ахырда, түзмичә, ул терсәге белән Талипның кабыргасына төртеп алды.* Ә.Еники

**Төртеп бару** Даими төртү. *Ул үз инициативасы белән бөтен ваклыкларына кадәр аерым бер дәфтәргә төртеп бара.* Г.Галиев. *Күпчелек каләм әһелләре көтмәгәндәрәк башына килгән төрле уй-фикерләрен көндәлек битләренә яки аерым кәгазь кисәгенә төртеп баручан.* З.Мансуров

**Төртеп бетерү** Ахырга кадәр, барысын да төртү. *Сарымсакларны төртеп бетергәч, Флүрә апа, авызы кибеп, өенә кайтып китә.* Акчарлак

**Төртеп җибәрү** Кинәт көч белән төртү. *Ул капканы бик каты итеп төртеп җибәрә.* Әкият. *Ана кулын суза улына, Төртеп җибәрәләр ананы ---.* Ф.Кәрим. *Хәлим күкрәгенә сикергән этне ачу белән төртеп җибәрде.* Совет әдәбияты

**Төртеп килү** Яңа төртә башлау. *Блокаданың беренче елында укуны калдырып торгач, унынчы сыйныфта тавышларыбыз калынайган, кыяфәтебездә ирләр чалымы сизелә башлаган, мыек төртеп килгән егетләр идек.* Казан утлары

**Төртеп кую** Көтмәгәндә төртү; бер мәртәбә төртү. *Гыйльметдин сары кашлы егеткә төртеп куйды: ишеттеңме?* И.Гази. *Шунысын да төртеп куегыз: бакчаны утыртканга быел унсигез ел.* Н.Фәттах

**Төртеп тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта төртү. --- *Картның кабыргаңа төртеп торуы ошады сиңа.* Р.Ишморат. *Кәҗә бәтиенең маңгаеннан күренер-күренмәс кенә булып нәни мөгезләре төртеп тора.* Р.Мөхәммәдиев

**Төртеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барысын да төртү. *Моның өчен карандаш белән үзең теләгән урыннарга төртеп чыгарга яки бәрхет тукымадан йолдыз, ай, йөрәк формасында кечкенә фигуралар кисеп әзерләргә кирәк булган.* Р.Борһаниева

**ТӨРҮ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәне кат-кат бөкләү, бөтерү. *[Фәттах Исламов] иренеп кенә кесәсеннән төргән газета чыгарды, аның почмагын ертты да зур итеп тәмәке төреп кабызды.* Ф.Кәрим. *Камыр кисәкләрен төреп, катламалар ясарга, өсләренә йомырка сылап, шикәр комы сибәргә [кирәк].* Серле календарь

2) *сөйл.* Тәмәкене яисә наркотик матдәләре булган үсемлекләрдән ваклап, төеп эшләнгән массаны кәгазь кисәгенә салып, тыгыз итеп бөтерү. *Мөкебай тагын берне [кәҗә тоягын] төреп бирде.* Н.Әхмәдиев. *Аның артыннан бүтәннәр дә тәмәке төрделәр.* Г.Кашапов

3) Берәр нәрсәне чүпрәккә, кәгазьгә һ.б.ш. урау. --- *Туйбикә кендек әбине чакырып алды һәм әлеге кургашын кисәген углының күлмәк җиңенә төреп бирде.* М.Хәбибуллин. *Аркадий Динә алып килгән бик шәп колбасаны, ак кәгазьгә төреп, бер читкә алып куйды.* Б.Камалов

4) Берәр кешене материя, кием белән тыгыз итеп урау; җылы киендерү. *Күз ачып йомганчы төлке юрганын китерделәр, кенәгинә баланы юрганга төрде дә ятакка салды.* М.Хәбибуллин. *[Ким] яңадан йоклап китәргә тырышып, башын юрганга төрде.* Н.Акмал. *Малайны Фатыйма үз алдына төреп утыртты.* Ә.Гаффар // Берәр нәрсәгә киендерү. – *Әгәр дә Таисия исемле бу сылу ханымны шундый ук киемнәргә төрсәң, Мария Нагая, кояш каршындагы ай кебек, тәмам төссезләнеп калачак, валлаһи, – диде [Серадов].* З.Фәтхетдинов

5) Уратып алу. *Кайгыда зәңгәр күз дә карасу шәүлә белән өретелә, алсу яңаклар да казылык төрген эчәге сыман кипшереп, юкарып һәм сарыга сабышып калалар.* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Бөтен яктан әйләндереп каплап алу // Күмү, урау. *Яшькә төреп күмдек түгелме соң кайнар яшьлекне?* М.Җәлил. *Ул [кар] бөтен тирә-якны акка төрә.* Ф.Галимуллин

7) *күч.* Дөреслекне нәрсә дә булса артына яшерү, нәрсә белән дә булса каплау, өртү. *Ирекле ярату, имеш! Син үзеңнең йөгәнсезлегеңне шушы сүз белән төрмәкче буласың.* Н.Исәнбәт

8) *күч.* Нәрсәгәдер бәйләп, шуның аша бирү. *Үзен генә түгел, димәк, әнисен дә ипсез хәлгә калдырды түгелме соң ул, күңелендәгесен сүзләргә төреп әйтте [Нияз].* Г.Әдһәмова. *Шулай ук авторның үз күңел халәтен үтемле образларга төреп бирүе ошый.* Мәдәни җомга

**Төрә бару** Барысын да эзлекле рәвештә төрү. *Лепер-лепер җиргә төшкән яфрак кар чүп-чар патшалыгын да ямьгә төрә бара...* Г.Әдһәмова

**Төрә башлау** Төрергә тотыну. *Маңгай тирләремне сөртеп алдым да, урындыкка утырып, махорка төрә башладым.* Ш.Усманов. *Миңлебай ефәк белән сөлгене яхшылап төрә башлады.* Н.Яһудин

**Төреп алу** Тиз генә төрү; тулысынча төрү, тоташ әйләндерү. *Тукта, тәмәке төреп алыйк башта.* И.Гази. *Ул ягы әллә ни уңайлы булмаса да, шулай да, саклык белән эш иткәндә, авылны төреп алырлык юллар бар.* Ф.Хөсни

**Төреп бару** Һәммәсен эзлекле төрү. *Быел районда игеннәре җыеп алынган кырларда саламны да шунда ук рулоннарга төреп баралар.* Әлки хәбәрләре

**Төреп бетерү** Тулысынча төрү, бик нык төрү. *[Инженер абый] калай торбаларны әллә ниткән ак кәгазьләргә төреп бетерде.* Т.Нурмөхәммәтов

**Төреп җибәрү** Тиз генә төрү. *Мә, Миңнулла абый җаным, төреп җибәр, миннән булсын яхшылык.* И.Гази. *Утыр, дускай, берне төреп җибәр, Сандугачлар таушын тыңларбыз.* Ә.Ерикәй

**Төреп кую** Алдан ук төрү; төреп әзер хәлгә китерү. *Берәүләр мендәр өстенә ап-ак сөлге салып, китүченең җылысын алып, сөлгене төреп куйдылар.* Я.Зәнкиев. *Аны йомшак утыргычка яткырып, баш-аягыннан төреп куйгач кына, Солтанның аңына барып җитте: «Нишли ул?»* Г.Гыйльманов

**Төреп тору** Даими төрү; төрү процессында булу. *Мәетне Шәмәрдән карттан юдырганнар да кәфенгә төреп торалар.* И.Гази. *Җанын төреп торган кабык салып ташланды.* Н.Гыйматдинова

**ТӨРҮ** II *и.* 1) Берәр нәрсәне тукыма, целлофан, фольга, кәгазь һ.б.ш.

материалга матур итеп яки һава кермәслек итеп урау эше. *Казанда, нанотехнологияләрдән файдаланып, сыгылмалы төрү материалы эшләп чыгаручы завод ачылды.* Безнең гәҗит. *Яңа җиһазларда продукция җитештерү, сыйфатны яхшырту, ассортиментны баету, әзер продукцияне төрү яки фасовкалау мөмкинлекләре бирәчәк.* Безнең Чирмешән

2) *махс.* Дәвалау яки косметик максатларда тәнгә махсус кремнар, мазьлар сөртеп, гәүдәне махсус тукыма яки целлофан белән әйләндереп алудан гыйбарәт процедура. *Белгеч фикеренчә, салоннарда башкарыла торган мезотерапия, төрү, тукымаларга тирәнтен массаж кебек процедуралар [целлюлитны дәвалаганда] яхшы нәтиҗә бирә.* Шәһри Казан

**ТӨРҮЛЕ** *с.* Төрелгән, төреп куелган, төргәкле. *Әхмәт, мәгариф эшчеләре союзы правлениесеннән кайтканда, култык астында сары кәгазьгә төрүле бер төенчек алып килде.* Ш.Камал. *Иң эчке сандык эчендә – төрүле калын кәгазь.* Г.Хөсәенов

**ТӨРҮЧЕ** *и.* Җитештерелгән әзер нәрсәне тукыма, целлофан, фольга, кәгазь һ.б.ш. материалга матур итеп яки һава кермәслек итеп төреп торучы эшче. *Флария Мәһдиева икмәк заводына төрүче булып урнашкан.* Туган як

**ТӨРЧӘ** *и. биол.* Төр эчендә берберсеннән кайбер үзенчәлекләре белән аерылып торган аерым затлар, нәрсәләр (үсемлек, хайван, бөҗәкләр) төркеме. *Башка туфраклардагы шикелле монда да комлы, балчыксыл, балчыклы төрчәләр очрый.* Җир һәм туфрак. *Иртә өлгерешле ак башлы кәбестәне һәм чәчәк кәбестәне тышка чыгарып утыртырга 50–60 көн калгач чәчәләр, калган сортлары һәм төрчәләре, шулай ук гәрәнкә 35–40 көн калгач чәчелә.* Йорт эшләре

**ТӨС** *и.* **1.** 1) Җисемнәрнең билгеле бер спектраль составтагы яктылыкны күрү тойгысы тудыра торган үзлеге; җисемнең яктылык тоны. *Ак төс – пакь төс. Беренче кар төсе, Он төсе, сөт төсе, гөнаһсыз яр төсе.* Г.Афзал. *Күзләр төсләргә үтә дә сизгер, җан исә дөньядагы һәр ымга сизгер.* Г.Гыйльманов. *Сары, алсу һәм кызыл төсне тозга тимер күгәреге бирә.* Кызыклар дөньясында // *сәнг.* Рәсем сәнгатендә буяулар кушылмасы, колорит. *Рәссамнарга өлге булыр төсләр – җиде күктә ---.* Сөләйман. *Һәр рәсемдә төсләр хикмәте, йөзләр характеры, оста композицион төзелеш, хәрәкәт, ургылып торган ритм күзгә ташлана.* Р.Туфитуллова

2) Йөз, чырай. *Кешенең кемлеген төсеннән белеп булмый, эшеннән белеп була.* Мәкаль. *Скрипач, кырык-илле яшендәге карт, үзенең чын дусты – скрипкасы белән халык алдына чыкты һәм, бик аз гына сызгалап карап, төсен бик моңлы сурәткә кертеп, акрын гына уйный да башлады...* Ф.Әмирхан. *Иптәш, бала фаҗигасе давылында Чорнап алган авыр хисләре, бөтен һушын алып, хатынының Ак көл иткән иде төсләрен.* Ф.Кәрим

3) Матурлык, чибәрлек. *Галиябану төс белән дә авылда бер иде, акыл белән дә өстен булып чыкты.* М.Фәйзи. *Төс ягына килгәндә, миндә юк та юк инде ул. Күрәсез: җирән чәч, сипкелле бит!* Т.Таһиров

4) Кешенең билгеле бер кыяфәте, килеш-килбәте. --- *Егет бераз базымын җуебрак калды, шулай да ак мамык сыман кулны учына алды һәм тышка күп көч салган төс чыгарып кысты.* Х.Камалов. *Азрак кырын салып киелгән бүрек, пилотка, сирәк-мирәк кенә күренгән фуражкалары аларга егетлек төсе кертеп тора.* З.Зәйнуллин

5) Нинди дә булса күренеш, сыйфат. --- *Дүрт тәрәзәгә бу пәрдәләрне корып җибәргәч, өйгә икенче төс үк кереп киткән кебек булды.* Г.Ибраһимов. *Нәкъ менә театр каланы бөтен итә, аңа затлы төс бирә.* Мәдәни җомга. *Көчсезрәк гыйшык кыйнала һәм хурлыклы төстә качып китәргә мәҗбүр була.* Кызыклар дөньясы

6) *күч.* Ямь. *Үз кул көчем керде [йорт-каралты төзүгә], шулай да төс бирә алмадым.* М.Хуҗин. *Карыйбыз бары тик сүнгән учакларга, искә төшерәбез сабыйларның шат авазын, икмәк исен, тормыш төсен, матчаларда бишек тирбәлүен...* Р.Әхмәтҗан

7) *күч.* Берәр-эш-хәл, күренешнең барышында, үтәлешендә билгеле бер форма, рәвеш. *Шау-шу, кычкырыш, шашкынлык бөтен өйне, йортны басты. Барган саен, тагын яманрак котыру төсенә керде, мич буенда такта шүрлек бар иде, берсе, ашыгып, куркынып, шуны актарырга керешә дә койрыклы тере шайтан тоткан кебек коты очып кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Алар --- аяусыз төстә кытыкларга, акыртып көлдерергә тотынды. Култык аслары да, кабыргалары да, табаннары да калмады.* Ә.Гаффар

8) *күч.* Эш-хәлнең барышында борылыш, яңа юнәлеш. *– Һич тә мәшәкатьләнмәгез, мин хәзер китәм, – диде Килдебәков, очрашуга рәсми төс кертмәскә тырышып.* Г.Гомәр. *Бәрелеш коточкыч төс ала.* С.Шакир

9) *күч.* Истәлек, ядкәр, хатирә. *Бу куакны язгы кичләрдә Үстердем мин, төсең булсын дип ---.* Ф.Кәрим. *Мәрхүмә әнкәйгә тагын бер кат рәхмәт, фронттан җибәргән һәр кәгазьне төсем итеп саклаган, җанкисәгем.* Ш.Рәкыйпов

10) *күч.* Эш-хәлнең асылы, нечкәлеге. *Җил күтәрсә читен пәрдәнең, Мин уйлаган идем, эчке төсе Ачылыр, дип, төнге хәлләрнең...* К.Булатова. *[Шигырь] Үз төсен таба, калыбын таба, Ныгый, шомара, әйтерсең чуер ---.* Г.Рәхим

11) *күч.* Бизәк. --- *Һәр җыр, Ренат фикеренчә, үзенчәлекле музыкаль төскә ия булырга тиеш.* Казан утлары

12) *күч.* Төр, сорт. *Милләтчеләрнең бөтен төрләрен, оппортунистларның һәр төстәгесен үрчетеп яткан бит ул Казанында.* Ф.Сафин

**2.** *хәб. мәгъ.* Килешле, лаеклы, муафикъ. *Арыслан көче төлкегә хас түгел, төлке хәйләкәрлеге арысланга төс түгел.* Мәкаль. *Озак торды открытка шунда, чәчәксез тау рәсеме янәшәсенә төс иде ул.* М.Хуҗин

**3. төсендә** *рәв. мәгъ.* 1) Буларак. *«Һәм шул законның искәрмәсе төсендә... Жан иртәгә яки берсекөнгә төндә доктор Ярович катына барырга тиеш», – диде [Виктория].* Ш.Рәкыйпов

2) Рәвешендә. *Бу эш махсус программа белән, либреттистлар өчен*

*кыска сроклы курс-семинар үткәрү, музыка белгечләренең системалы лекцияләрен оештыру төсендә була.* Казан утлары

◊ **Төс бетү** *к.* **төс качу**. *Әй, фәлән бай! --- Корсагың шиңгән, төсең беткән... Ничек булдың болай?* М.Гафури. **Төс биру** 1) Ябыгу, сулу, йөз, кыяфәт үзгәрү (авырудан, кайгыдан). *[Мәдинә] бераз төс бирергә өлгергән, ябыккан.* М.Хәсәнов; 2) Килешү. *Төс бирмәгән малны асрама.* Мәкаль. *Харам мал төс бирми.* Мәкаль. **Төс бозылу** Чырайга канәгатьсезлек билгесе чыгу, чырай сытылу. *Мин шул сүзне әйткәч, Заһир әфәнденең тәмам төсе бозылды, кәефе китте.* Г.Тукай. **Төсе калмау** *к.* **төс качу** (*2 мәгъ*). **Төсен дә күрәсе килмәү** Берәр кешене күрәсе, аның турында ишетәсе килмәгәндә әйтелә. *Чистый туеп беттем инде үзләреннән: төсләрен дә күрәсем килми.* Г.Камал. **Төсен дә күрмәү** 1) Берәр кешене белмәү, таныш булмау яки бик озак вакыт күрмәү; 2) Берәр нәрсәнең булмавы, аны белмәү, шуннан файдаланмау. – *Әтәчләрне суеп бетерсәң, гомереңә йомырка төсе күрмәссең, – дип куйды [ул].* М.Гафури. **Төсен дә күрмим** Берәр нәрсәдән, кешедән бик нык туйганда әйтелә. **Төсе түгел** Кемнең дә булса берәр нәрсәгә хакы яки эшләү мөмкинлеге булмау турында. **Төс җибәрү** *к.* **төс җую**. *Бу юлы ул аңа ничектер төс җибәргән, кояшта уңган кебегрәк тоелды.* Ф.Галиев. **Төс җую** Матурлык югалу. *Зур, матур күзләре төсен җуйса да, ул хатын шактый чибәр булган, имеш.* А.Хәсәнов. --- *Сине тәмам туйдырып, инде үз йөзләрен, үз төсләрен җуя башлаган кешеләр турында шигырь язалар димени?* Ф.Яруллин. *Елыйм дип уйлаган идем мин. Чыкмаган яшем дә. Төс җуйган фирәзә йөзегем Кемнәрдән яшерәм?* Л.Газизова. **Төс качу** 1) Баштагы үз төсе уңу. *Яңгыр, юеш, салкын җил астында төсләре качкан матур колыннар ду килеп, әче тавыш белән кешнәшеп уйнарга тотындылар.* Г.Ибраһимов; 2) Куркудан, каушаудан, борчылудан, авыртудан йөз агару. *Куркып төсе качкан баланы Вандал үзе ала кулына ---.* Ф.Кәрим. *Нурия кып-кызыл булып кызарды, аннары төсе качты, иреннәре тетрәнде.* Г.Ахунов. – *Ә, ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят! – диде уңган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.* Ә.Еники. **Төскә чыгу** Кәеф, хиснең йөздә чагылуы. **Төс керү** Тазару, матурланып китү. *Тукта, карыйм әле, пират тормышы нишләтте икән сине? Төс кергән, егетләнеп киткәнсең.* М.Юныс. **Төс килү** Килешле булу. *Бу кайда укый икән? Әмма биле төс килгән бит?!* С.Рәмиев. *Аның йөзе, беләкләре әнә шул күлмәгенә бик тә төс килеп тора.* Г.Бәширов. **Төс китү** *к.* **төс качу**. *Бөтенләй төсләрең киткән, авырыйсыңмы әллә?* Ш.Камал. *Әби урындыкка лып итеп утырды. --- Төсе китте.* Н.Дәүли. *Ул тәмам хәлдән таеп, төсләре киткән, аның өстенә карарга да куркыныч иде.* Ш.Маннур. *Ай сеңлем, ни булды? Нигә төсең китте?* Г.Бәширов. **Төс куну** *к.* **төс керү**. *Бер-ике тәмәке суырырлык вакыт үтүгә, йөзенә төс кунган режиссёр кире әйләнеп керде.* А.Әхмәтгалиева. **Төс салу** Элеккеге матурлыкны, тулылыкны югалту. *Аның битен вак җыерчыклар каплаган, чәче агарган, ә тешләре – матур булып тезелеп торган вак кына тешләре – һаман да төсен салмаган иде әле.* Г.Бәширов. **Төс ташлау** *к.* **төс салу**. *Ул да төс ташлаган, тик һаман да шул игелекле Сания булып калган.* Г.Тарханова. **Төстән китү** *к.* **төс качу** (*2 мәгъ.*). *Хаҗи бөтенләй төстән китеп: «Ярабби, алай уйламадым», – [диде].* Г.Тукай. **Төстән чыгу** Җәйкыш төсне алыштыру. *Куян төстән чыга, әйткән сүз истән чыга.* Мәкаль. **Төс югалу** 1) *к.* **төс качу**; 2) *к.* **төс салу**

**ТӨС-БАШ** *җый. и.* Тышкы кыяфәт, килеш-килбәт. *Төс-баш ягыннан да, әдәп-әхлак ягыннан да, әти-әнисе ягыннан да – ну, менә бер генә дә килмәгән җире юк туташның!* Ә.Еники. *Төс-баш иде күрер күзгә арык, Өчпочмаклы кара хәбәр алдык.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ТӨС-БИТ** *җый. и.* Йөз, чырай, тышкы кыяфәт. *Төс-бит, буй-сын шәп, әлбәттә.* В.Нуруллин. *Озаклап эзли торгач, төскә-биткә дә, буйга-сынга да туры килә торган үсмер егет булып Шириздан табылды ---.* Г.Ахунов

◊ **Төсе-бите калмау** Куркудан, каушаудан, борчылудан, авыртудан йөз агару. --- *Кулына төенчеген тотып, Нюра үзе килеп керде. Төсе-бите калмаган, агарынган.* Г.Бәширов

**ТӨС-БУЙ** *җый. и.* Буй-сын, тышкы кыяфәт. *[Егет] төскә-буйга бик чибәр, зифа.* Р.Төхфәтуллин

**ТӨС-БУЯ́У** *и.* Төрле төсләр, буяулар. *Скрябинның «төсле музыка» серләрен ачу алдында торганлыгын да, Чурленисның яңгырап торган төсбуяулары да, Блокның күз алдында төсле таплар пәйда булып, шулар «сөйләшә башлагач» шигырь язарга тотынуын да белми әле ул.* Казан утлары

**ТӨС-ЙӨЗ** *җый. и. к.* **төс-бит**. *Әлеге хатынның хәрәкәтләрендә, хәтта төс-йөз чалымнарында хатыны Гөлнисаның чалымнарын күргәндәй булды [ул].* М.Хәсәнов. *[Федора] гаҗәеп гүзәл сынлы, төскә-йөзгә чибәр, күзләре гелән ут яна.* М.Хәбибуллин

**ТӨСКӘ́Ү** *ф. диал.* Берәр озынча, нәзек нәрсәне селкү. *Көчле [койрыкларын] төскәгәндә, [арысланны] ике фил саклап тора.* Ш.Камал

**Төски төшү** Азрак төскәү

**Төскәп алу** Тиз генә төскәү

**Төскәп кую** Бер мәртәбә төскәү

**Төскәп тору** Әледән-әле төскәү, хәзерге вакытта төскәү

**ТӨС-КИЛБӘ́Т** *җый. и. к.* **төс-баш**. *Күпме гасырлар яшәгән Үзгәртми төскилбәтен. Самурайлар саклап калган Японнарның милләтен.* Н.Әхмәдиев. *Аны тыңлаганда, җырчының буйсыны, төс-килбәте күз алдына баса.* С.Шәрипов

**ТӨС-КЫЯФӘТ** *җый. и. к.* **төсбаш.** *Әле булса күз алдында яшь хатынның серле төс-кыяфәте торды.* Н.Фәттах. *Югыйсә бик матур тавышлы, ягымлы тембрлы, төс-кыяфәткә чибәр, зифа буйлы дистәләгән җырчы бар барлыгын, әмма бөек җырчы --- бер гасырга бер-ике генә туа.* Сәхнә

**ТӨСЛӘВЕЧ** *и.* **1.** *диал.* Төтәткеч. *Төсләвеч дөнья тутырып төти башлады.* Ялкын

**2**. *с. мәгъ.* Төтәсләү өчен кулланыла торган. *Төсләвеч гөмбә*

**ТӨСЛӘНҮ** I *ф. төш. юн. к.* **төсләү**. *Халык, гөмбә белән төсләнгән умарта оясы кебек, кемнең ни әйткәнен аңламаслык итеп шаулады.* К.Нәҗми

**Төсләнә бару** Торган саен төсләнү

**Төсләнә төшү** Бераз төсләнү

**Төсләнеп алу** Тиз генә төсләнү

**Төсләнеп китү** Кинәт төсләнү

**Төсләнеп тору** Даими төсләнү

**ТӨСЛӘНҮ** II *ф. к.* **төсләнү**. *Күренәләр таулар төтенгә әйләнеп, күк төсләнеп.* Н.Исәнбәт. *Һәм җиһан шәмәхә Төсләнә берара.* Р.Мөхәммәтшин

**Төсләнә бару** Торган саен төсләнү

**Төсләнә төшү** Бераз төсләнү

**Төсләнеп җитү** Тулысынча төсләнү, тиешле дәрәҗәдә төсләнү

**Төсләнеп китү** Кинәт төсләнү

**ТӨСЛӘ́Ү** *ф.* 1) Төтен өрдерү

2) Борынгы ышанулар буенча, җен кагылган яки күз тигән дип саналган кешегә, хайванга көйрәп торган имән гөмбәсе, артыш таягы һ.б.ш. нәрсәләрнең төтенен өрдерү. *Түшәктә яткан авыруны яки яңа туган баланы җиде әйбернең төтене белән төсләгәннәр.* Татар мифлары

**Төсләп алу** Тиз генә төсләү

**Төсләп җибәрү** Тиз генә, җиңелчә генә төсләү

**Төсләп тору** Даими төсләү

**Төсләп чыгу** Һәммәсен төсләү

**Төсли бару** Барысын да билгеле бер тәртиптә төсләү

**Төсли төшү** Бераз төсләү

**ТӨСЛЕ** I *с.* 1) Нинди дә булса бер төсе булган. *Тамырлы катлауның алгы өлеше төсле катлау дип атала.* Биология. *Бу пәрдә хрусталикны да, төсле катлауны һәм мөгез катлауны да икегә бүлә.* Кызыклы ихтиология

2) Нинди дә булса бер төскә буялган. *Шәһәрдәге ювелирларның иң өлкәне Касиев, гадәттә бриллиант ташларга буяу яисә төсле эмаль катнаштырмыйлар, диде.* З.Фәтхетдинов

3) Берьюлы күп төсләр катнашкан. *Күңеле күтәрелгән уйлап табучы үз экспериментларын тагын да киңәйтә: терменвокс яңгырашына төсле музыканы китереп куша.* Идел

4) Ак һәм карадан башка төстә булган. *[Самат] --- әкият китаплары, рәсем ясарга альбом, төсле карандашлар күтәреп кереп тә җитте.* Г.Галиева. *Күбесе төсле булган фотосурәтләрдә безнең чор кешеләре --- күзаллана.* Р.Гаташ

5) Үз, табигый төсендә күрсәтә торган (телевизор тур.). --- *өйдә төсле телевизоры, татарчасын, русчасын, чит илнекеннән иң матур көйләр язылган магнитофоны --- [бар]. Ял итәргә кешегә тагын ни кирәк?* Р.Төхфәтуллин

6) Тимер һәм аның эретмәләренә кермәгән барлык металларга бәйләнешле. *Алюминий һәм бакыр промышленносте – төсле металлургиянең иң мөһим тармаклары.* География. *Нефть, газ, кара һәм төсле металлургия, урман, «оборонка», төзелеш индустриясе һәм авыл хуҗалыгы – барысы да Көнбатыш кредиторларына күчеп бетәр иде.* Татарстан

7) Билгеле бер килбәтле, йөзле. *Әле мин дә сорашып бетерә алмадым, ул кыз ни төсле соң?* Г.Камал

8) Билгеле бер рәвешле, формалы. *Җир йөзендәге һәр урыннар бер төсле түгел бит.* Г.Тукай

**ТӨСЛЕ** II *бәйл.* Кебек, шикелле, сыман. *Рамил, бәхет кошын ауларга чыккан оста мәргән төсле, гел очынып йөрде.* В.Имамов. *Син аңарга шундый охшагансың, Бәхетсездер шуның төсле ук.* К.Булатова. *Ләкин кызның аяклары җиргә кадакланган төсле, куптарып булмый.* Н.Гыйматдинова

**ТӨСЛЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Берәр төрле төскә керү, төрлегә әйләнү

2) Берәр төрле сыйфатка ия булып китү, берәр кешегә охшап китү

**Төслеләнә бару** Торган саен күбрәк төслеләнү

**Төслеләнә төшү** Бераз төслеләнү

**Төслеләнеп алу** Бераз төслеләнү

**Төслеләнеп китү** Кинәт яки соңгы арада төслеләнү. *Әмма шагыйранә агышлы куәт илә акрынлап үзенә җәлеп итә барган төп проблема төслеләнеп һәм тулыланып китте.* Ф.Яхин

**ТӨСЛЕЛЕК** *и.* Билгеле бер төстә булу сыйфаты. *Озынлыкларына карап, аларның төрлечә үзлекләре бар (күренүе, төслелеге, үтеп чыга алу сәләте һәм башкалар).* Физика курсы. *Суның сыйфаты санитар-гигиеник таләпләргә җавап бирә (тимернең күләме – 3,69 мг/л дан 0,3 мг/л га, төслелек – 93,7 градустан 20 градуска, болганчыклык 28,2 мг/л дан 1,5 мг/л га кадәр киметелде).* Сарман

**ТӨСЛЕТӘНЛЕЛӘР** *и. күпл.* Ак тәнле расага кермәгән кешеләр

**ТӨСМЕР** *и.* 1) Берәр төснең бик аз гына аерылып торган төре. *Кушыла торган төсләрнең берсе күбрәк алынса, бөтенләй теләмәгән төсмер барлыкка килергә мөмкин.* Серле календарь. *Физик-химик күрсәткечләре буенча суның составында кальций, калий, натрий, сульфат гидрокарбонатлары, сероводород ионнары күп булу аркасында, су төбендәге токымнарда хасил булган кристаллар суга зәңгәрсу төсмер бирә.* Биектау хәбәрләре

2) Берәр нәрсәнең, күренешнең үз ишләреннән бер ягы белән сизелерсизелмәс кенә аерылып торган билгесе. *Әфганстанда таулар күп ---. Һәркайсының үз төсмере, матурлыкта үз байлыгы.* М.Хуҗин. --- *Гомер чылбырына күңелнең һәр халәте, тормышның һәр мизгеле нindидер төсмер өсти, карашлар иркенәя, хәрәкәт тотрыклы үзгәрә бара.* Ф.Сафин

3) *күч.* Нәрсәдә дә булса хис, тойгы, рухи халәтнең беркадәр чагылышы. *Текстка ныклап кисәтү, куркыту төсмерләре килеп керә.* С.Шәмси. *Заманалар уза тора, мәкаләләргә дә яңа мәгънә, һич көтелмәгән төсмерләр өстәлә тора.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Үзенчәлек. *Төсләрнең талгын күчеше, сабыр моң М.Килдебәкова иҗатының төп төсмерләре булып торалар.* Казан утлары

**ТӨСМЕРЛӘНЕШ** *и.* Билгеле бер төсмер алу. *Төрдәш мәкальләрнең мәгънә төсмерләнешендә үзенчәлек була.* Н.Исәнбәт

**ТӨСМЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Билгеле сыйфатлары белән күз алдына килү, гәүдәләнү. *Минем күңелдә шундый композиция төсмерләнә, шундый...* Ә.Мушинский. *Анда әллә кемнәр бар: цирк хуҗасы Никитин да, Карәхмәт куша-*

*матлы төрек көрәшчесе дә, Дию образында төсмерләнгән «божий фирка» башлыгы Гайнан ишан Вәисев тә ---.* З.Мансуров // Хәтердә саклану. *Күз алдында эссе әвеннәр, печән богыллары, ашлык кибәннәре, Сабан туйлары – син берсендә дә юк, йөзең төсмерләнмәде.* Ә.Гаффар

2) Билгеле бер дәрәҗәдә генә күренү, шәйләнү. *Әле шактый ерак булса да, чиркәү һәм мәчет манаралары төсмерләнә иде.* Ә.Гаффар. *Төсмерләнә ерактан Сихоте-Алинь таулары.* Ә.Маликов

3) Берәр ничек характерлану, ачылу. *Башта барлы-юклы материалларны тупларга тотынды, зиһенендә магистральнең азмы-күпме тарихы төсмерләнде.* С.Шәрипов. *Әлеге икәү бу тормыштагы ваклыклардан бераз югарырак, үзләре дә тирә-ягымдагы кешеләрдән матуррак булып төсмерләнә.* Казан утлары

4) Берәр нәрсә бик аз сиземләнү. *Аның йөзендә әллә шунда елмаю, әллә шунда сагыш, әллә шунда кызгану чаткысы төсмерләнде.* Ә.Гаффар. *Сафинның аңа каршы килмәячәге алдан ук төсмерләнә иде.* Р.Айзатуллин

**Төсмерләнә бару** Торган саен ныграк төсмерләнү. *Табигый сәләтләре нығыган, көч вә куәт ала барган саен, хәзер татар поэзиясенең төп көчләре саналырга лаек буын вәкилләре арасындагы аерма ачыграк төсмерләнә барды ---.* Т.Галиуллин. *Караган саен, ул сыйфатлар ачыграк төсмерләнә барды.* М.Кәбиров

**Төсмерләнә башлау** Төсмерләнергә тотыну. *Ниһаять, күз алдында ак шәүлә төсле генә булып урман төсмерләнә башлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Бераз баруга, сезгә Кирмән җиренең төньяк-көнбатыш чиген саклаган кече хәрби ныгытма булган авыл төсмерләнә башлар.* Р. Газиз

**Төсмерләнә төшү** Бераз төсмерләнү

**Төсмерләнеп китү** Кинәт аз гына төсмерләнү. *Үзенә кул болгап озатып калучылар арасында, бераз читтәрәк, нindидер таныш сурәт төсмерләнеп киткән сыман булды түгелме соң?!* Р.Мөхәммәдиев

**Төсмерләнеп тору** Күпмедер вакыт яки хәзерге вакытта төсмерләнү. *Аның матур күрәнсу йөзендә, чем кара чәчләрендә, килешле киң иягендә, сүрәнләнгән күзләрендә аптырау һәм җәлләү төсмерләнеп тора иде.* Х.Камалов

**ТӨСМЕРЛӘҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне, кешене якынча хәтергә төшерү. *Рифкать аны аз гына төсмерли, бер-ике тапкыр очрашканнары да бар.* Р.Вәлиев // Берәр кешене, йөзенә, кыяфәтенә карап, тулысынча хәтергә төшерү. *Ул бу ир кешенең салынып төшкән озын сары мыегын күрү белән, аның кем икәнлеген төсмерләде.* А.Расих. *Тутәйне таныдым, сезне, балаларны төсмерләдем ---.* Ә.Баян // Гомумән хәтергә төшерү. *Әгәр сәрхуш түти баланы әз-мәз төсмерләп шик белдерә икән, зарар юк.* Н.Гыйматдинова. *Фаяз абый: «Вам кого?» – дип тә, «Ни йомыш, энекәш?» – дип тә сорамады, фәкать елмаюын җыярга онытkan килеш, уйчан карашы белән мине төсмерләргә тырышты.* Ә.Дусайлы

2) Берәр нәрсәнең, кешенең үзенчәлекле сыйфатларын билгеләү, характерлау. *Байның психикасын шулай төсмерләгәннән соң, Гафури ачу белән үзеннән шул юлларны өсти.* М.Җәлил

3) Күз алдына китерү. *[Табигать] Баш өстебезгә зәңгәр чатыр итеп күкләрен корган, киләчәкнең алтын капкаларын төсмерләү өчен, салават күпере кабызган ---.* Р.Низамиев. *Либреттист Җ.Фәйзи үз либреттосында Г.Тукайның шул идеясен дөрес чагылдырганмы һәм типларны Тукайча дөрес төсмерләгәнме?* М.Җәлил

**Төсмерли башлау** Төсмерләргә тотыну. *Менә син инде аның гәүдәсен, күзләрен, кыланышларын төсмерли башладың.* Г.Бәширов. *Аннары ул ап-ак түшәмне, ак стеналарны, ак халатлы кешеләрне төсмерли башлады.* Р.Вәлиев

**Төсмерли төшү** Бераз төсмерәү

**Төсмерләп алу** Тиз арада төсмерләү. *Әптерәй йөзе сула төшкән бу яшь хатынны төсмерләп алды.* Г.Бакиров. *Тик менә хәзер Наташа әйткәч кенә, Зәйтүнә аның көндез причалда милиционер китергән егет икәнлеген төсмерләп алды.* С.Сабиров

**Төсмерләп бетерү** Тулысынча төсмерләү. *Никтер төсмерләп бетерә алмыйм үзеңне...* М.Хәсәнов. *[Мирсәет:] Гафу, әфәндем. Мин сезне бик төсмерләп бетерә алмыйм.* Р.Мөхәммәдиев

**Төсмерләп калу** Төсмерләргә өлгерү. *Алар авылына концерт белән барганнары бар иде, Канифәне төсмерләп калган икән.* Н.Кобәш

**Төсмерләп китү** Җиңелчә генә, бераз гына төсмерләү. *Шулай ук әйтемнәр дә тик ятмыйлар: кирәк чагында, үзләреннән шулхәтле олы булган мәкаль абыйларының вәкарен ватып, хикмәтен хикмәттән чыгарып, берәр кисәген алып, үзләре кебек җөмлә кисәгенә әйләндерәләр дә берәр нәрсәнең очраклы бер ягын гына төсмерләп китәргә кушалар ---.* Н.Исәнбәт

**Төсмерләп кую** Бераз төсмерләү. *Гали менә шулай башта бу хатынны төсмерләп кенә куйса да, ахырда кем икәнен белде.* М.Гафури

**ТӨСМЕРЛЕ** *с.* 1) Нәрсәгәдер охшаш, нәрсәнедер хәтерләтә торган

2) Үзенә генә хас сыйфаты, үзенчәлеге булган. *Чөнки халыкның борынгыдан килгән гореф-гадәт, тормыш үзенчәлеге, аның рухи йөзе, эчке табигате нәкъ шул көндәлек мөнәсәбәтләрдә вак төгәлләмәләрдә тагын да аныклырак, төсмерлерәк чагыла ---.* Н.Исәнбәт. *Безнең очрашу үзебезнеке генә, аерым төсмерле.* Р.Кәрами

3) Хәтере яхшы. *Төсмерле картkоры*

4) Төстәге. *[Борчакның бер төре –] кызгылт-миләүшә төсмерле ике төстә чәчәк ата торган басу борчагы (пелюшка).* Яшелчәчелек

**ТӨСМЕРЛЕЛЕК** *и.* Билгеле бер сыйфатка, үзенчәлеккә ия булу. *Иҗатында шигъри стиленең объектив өслүбе җиңә, бай төсмерлелек, ярым тоннар кими, башлангыч иҗатына хас куе сурәтлелекне, романтиканы еш кына тематик яңачалык, публицистик хөкем алыштыра.* Т.Галиуллин

**ТӨСМЕРСЕЗ** *с. диал.* 1) Төссез, төсе киткән; ямьсез. *Сәгыйдә апай да, утырган җирендә бер аягын алгарак сузып, чуарлыгы уңып беткән төсмерсез оегына куанмыйча гына карап:*

*– Бүләккә каршы бүләк бирмичә яхшы булмый инде ---, – диде.* Ш.Камал

2) Хәтерсез. *Төсмерсез яшьләр*

**ТӨСМЕРСЕЗЛӘНҮ** *ф. диал.* Төссезләнү; ямьсезләнү. *Кыз аның күз алдыннан, күңеленнән төсмерсезләнеп, ямьсезләнеп, каралып юкка чыкты.* Алга

**ТӨССЕЗ** *с.* **1.** 1) Буялмаган; төс бирә торган пигменты булмаган. *Ә Аит болдырдагы кәгазь әрҗәдән төссез вино сайлап алды да, ике фужер эләктереп, аның янына ашыкты.* Ә.Гаффар. *Лейкоцитлар төссез, шуңа күрә аларны канның ак күзәнәкләре дип атыйлар.* Биология

2) Үтәкүренмәле. *Егет төссез кашлы көмеш йөзеген учына яшереп, --- суга манчып чыгарса, ни күрсеннәр: йөзек кашы кызлар бите сыман алсуланып-алсуланып яна, ди!* Ә.Гаффар. *--- Блокнотка сүзләр язам... «Зәңгәр төтен. Яшел чирәм. Төссез яшь».* Р.Фәйзуллин

3) Тонык, күзгә бәрелеп тормаган. *Әйтерсең лә язмыш аны тереклек яралмаган, җан ияләре булмаган төссез, иссез һәм шомлы тынлык хакимлек кылган бер галәм утравына илтеп ыргытты.* А.Гыйләҗев. *Улы сыман ул да сәләмә киемдә, ситсы күлмәге күп юудан төссез чүпрәккә әйләнгән ---.* Т.Гыйниятуллин

4) Табигый алсулыгы югалган (йөз, бит тур.). *Ә кан эчмәгәндә кибәк кебек төссез бер нәстә инде.* З.Зәйнуллин // Хәлсезләнгән. *Болар хәзер элекке кебек елап ашарга да сорамыйлар. Булса, алларына килсә, беткәнче йотыгалар, булмаса, төссез, хәлсез сузылып ята бирәләр.* Г.Ибраһимов

5) *күч.* Бернинди хис чагылдырмый торган, салкын, нурсыз. *Габделбасыйрның йөзе матурлык белән аерырлык түгел иде: төссез генә соры күзләр, --- шактый ерынкы авыз, таррак кына маңгай.* Ф.Әмирхан. *[Камилнең] --- бернигә дә исе китмәгәнне чагылдырган төссез күзләре Саимәне үзенә тарта алмады.* Г.Галиева

6) *күч.* Шыксыз, ямьсез. *Төссез, соры көннәр үтеп киттеләр.* К.Тәхау. *Алда соры, төссез тормыш көтә.* Ә.Гаффар. *Хатын аның бер-берсенә охшаган төссез көннәренә ямь, яңалык кертә.* С.Шәмси // Күңелсез, төрлелек, яңалык булмаган. *Бу искергән алачыгым һәм караңгы, һәм төссез ---.* Дәрдемәнд. *Тик синең йорт-каралтыларың төссез күренә.* М.Хуҗин // *шелт.* Мәхәббәтсез, сөйкемсез, эчке нуры булмаган. *Аларның колга шикелле озын, шадра, төссез, ямьсез, кыек авызлы, кәкре аяклы кызларына, бүләге дә булмагач, эт барсынмыни?* Г.Камал

7) Үзенчәлекле билгеләре булмаган, көчсез. *Теге яисә бу әсәрнең теле ярлы икән, шапшак һәм төссез икән, бу – авторның наданлыгыннан яки ялкаулыгыннан килә.* Г.Бәширов. *Әмма шуңа карамастан негатив геройлар төссез, схематик булып чыга.* Д.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ.* Агарынып. *Төссез калу*

**ТӨССЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Төссез итү, төсен бетерү. *Беренче тәҗрибәдәге кебек аны төссезләндерәбез, суда юабыз һәм 2–3 минутка сыегайтылган иод эремәсенә салабыз.* Биология. *Тукымаларны җылытылган гидросульфит бик яхшы төссезләндерә ---.* Файдалы киңәшләр. *--- Олеин кислотасы бромлы суны төссезләндерә.* Химия

2) Ямьсезләндерү, нурсызландыру. *Бу --- тапшыруны төссезләндерә.* Безнең гәҗит

3) Үзенчәлекле сыйфатлардан мәхрүм итү. *Реаль җирлектә тумаган пафос образны төссезләндергән.* И.Юзеев

**Төссезләндерә бару** Торган саен төссезләндерү

**Төссезләндерә башлау** Төссезләндерергә тотыну

**Төссезләндереп бетерү** Тәмам төссезләндерү

**Төссезләндереп җибәрү** Бераз төссезләндерү

**Төссезләндереп кую** Көтелмәгән рәвештә төссезләндерү

**Төссезләндереп тору** Даими төссезләндерү, күпмедер вакытка төссезләндерү. *Бары тик аны төссезләндереп кенә тору мөмкин.* Ф.Яхин

**ТӨССЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Төсен югалту, уңу. *Күзләре көл сипкәндәй төссезләнсә дә, карашы горур, тәкәббер, вәкарь.* В.Имамов. *Бернигә көн кояшта ятканнан соң, ул төссезләнде.* З.Зәйнуллин

2) Ямьсезләнү, җансызлану, терелеге китү; хисләр чагылдырмау. *Күп эчеп, чөгендер кебек кызарган зур борыны, төссезләнгән күзләре аның бер усал кеше икәнлеген әллә кайдан әйтеп торалар.* Ф.Кәрим. *Каладан төссезләнеп, котсыз калып кайткан идең.* З.Хәким

3) Матурлыгы бетү, асылы югалу. *Гореф-гадәтләребез төссезләнә, татарлыгыбыздан ерагаябыз.* Безнең гәҗит

4) *күч.* Тоныклану, ямьсезләнү, гадәтигә әйләнү (тормыш тур.). *Шулар белән бергә табигатебезнең серлелеге дә кими, тормышыбыз төссезләнә.* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Тәэсирлелеге кимү, яме, тәме бетү (сүзләр тур.). *«Син миңа ошыйсың», «мин сине якын күрәм» диюләр тәмам онытылды, төссезләнде, уңды, тәме китте.* Ә.Гаффар. *Кешеләргә сөйләмәсәң, сөенечләр дә төссезләнә.* Ф.Яруллин

**Төссезләнә бару** Торган саен төссезләнү. *Ихтыяр сөйләгән саен, әнисенең йөзендәге нуры сүрелеп, күзләре төссезләнә барды.* Р.Вәлиев. *Сүнепсүрелеп үк бетмәсә дә, ул малайның йөз-сурәте һаман тоныклана, төссезләнә барды.* Г.Гыйльманов

**Төссезләнә башлау** Төссезләнү билгеләре күренү. *Чәчләр коела, сына, төссезләнә башлый, керфекләр коелып бетә.* Татарстан яшьләре. *Төссезләнә башлаган зәңгәр күзләрдә горурлык та, өметсезлек тә, аяныч та күрдем кебек...* Безнең гәҗит

**Төссезләнә төшү** Бераз төссезләнү. *Көлсу йөзе тагын да төссезләнә төште.* М.Хәсәнов

**Төссезләнеп бару** Торган саен ныграк төссезләнү. *--- Элеккеге Сабантуйлар белән чагыштырганда хәзергеләре бөтенләй төссезләнеп бара кебек.* Безнең гәҗит

**Төссезләнеп бетү** Бик төссезләнгән булу. *Минем кат-кат юудан уңып, төссезләнеп беткән өс-башым янында алар аеруча аерылып торалар иде.* Җ.Тәрҗеманов. *Дәреслектән дәреслеккә күчеп, шомарып, искереп, төссезләнеп беткән, бернинди эстетик кыйммәте калмаган хан заманындагы шигъри әсәрләр монда да байтак.* Р.Миңнуллин

**Төссезләнеп калу** Ниндидер вакыйгадан, тәэсирдән соң төссезләнү. *[Әби] үзе сулыгып, төссезләнеп калган.* Н.Гыйматдинова. --- *Саратовта кузгатылган эш егерменче еллардагы гаепләнүләр каршында төссезләнеп кала.* Р.Мөхәммәдиев

**Төссезләнеп китү** Көтмәгәндә төссезләнү. *Тирә-як аның өчен ничектер төссезләнеп китә, эче поша, бернәрсә эшлисе килми.* Г.Әпсәләмов. *Шәһәр һавасы килешмәгәнме, әллә хәсрәт җиле кагылгангамы, бу йөздән нур каччкан, саргаеп, төссезләнеп киткән кебек.* Р.Габделхакова

**Төссезләнеп тору** Даими төссезләнү; төссезләнгән кыяфәттә булу. *Күзләрем дә төссезләнеп тора кебек.* Л.Зөлкарнәй

**ТӨССЕЗЛЕК** *и.* Төссез булу сыйфаты. *Әлбәттә, бүгенге яшьләребезгә заманның төссезлек, нәселсезлек, ырусызлык, милләтсезлек, космополитизм чире йоккан.* Р.Вәлиев. *Шушы төссезлеге Әхмәтвәлине һаман хәрәкәтләнеп торырга, теленә салынырга, бүтәннәрнең күз уңына керү өчен, иң кимендә, җырлап җибәрергә мәҗбүр иткәнлеген бик сирәкләр белде.* Ф.Яхин

**ТӨСТӘШ** *с.* **1.** Бер төстәге. *Кыска чәчләрен, гадәттәгечә, лак сиптереп кенә тигезләп куйган, «эшлекле ханым» стилендәге соргылт күлмәген, күлмәгенә төстәш биек үкчәле туфлиләрен кигән кызы өйдән чыгып китәргә инде күптән әзер иде.* Ф.Мөслимова. *Ул көнне син елмаеп, күзләреңә төстәш яшькелт зәңгәр күлмәгеңне киеп, безне Сабантуй мәйданында көтәсеңдер кебек.* Татарстан яшьләре

**2.** *и. мәгъ.* Бер кешегә кыяфәте белән бик охшаш икенче кеше. *Зур бәйрәмнәрдә генә Мавзолей трибунасында күренә торган ярым хәрби киемдәге кара мыеклы кеше Сталин үзе түгел, ә аның төстәше (двойнигы) булган, имеш!* Ә.Еники

**ТӨС-ЧЫРАЙ** *җый. и. к.* **төс-бит**. *Тик иртәсен кызларның төс-чырайлары бөтенләй качкан иде.* С.Хафизов

**ТӨТӘПЛЕ** *с. диал.* Зур гәүдәле. *[Хәйрулла] үзенә караганда яшьрәк булган, бик төтәпле Газзә абыстайны эләктергән.* Ф.Бурнаш

**ТӨТӘС** *с.* Һавасы төтенле, бик вак тузан пәрдәсеннән гыйбарәт. *Мәхшәр кебек ыгы-зыгы тулы, төтәс һавалы пристаньнан чыгып, пароход йөрешен тизләткәч, рәхәт җиңеллек биреп, дымсу талгын җил исә башлады, эсселек сизелерлек басыла төште.* С.Сабиров

**ТӨТӘСЛӘВЕЧ** *и. к.* **төтәткеч**. *Булмәгә керү белән, аның карашы төтәсләвечкә төште.* М.Хуҗин

**ТӨТӘСЛӘГЕЧ** *и.* 1) *к.* **төтәткеч**. *Юкса бездә бер ертык битлек белән бер төтәсләгечтән башка нәрсә юк.* Ф.Яруллин. --- *Бер кеше чираттагы умарта стенасына сугылган номерны тикшерә һәм, очу тишегеннән төтәсләгеч белән төтәсләп, умарта капкачын ача.* Умарта кортлары. *Төтәсләгечегез, киракскә, ягып төтен бирерлек хәлдә булсын.* Өмет

2) Эчендә хуш исле матдәләр яндырыла торган савыт. *Күнлек төтәсләгече*

3) *дини* Христианлыкта келәү вакытында күнлек төтәсләү өчен чылбырларга асылган металл савыт. *Алтын төтәсләгеч*

**ТӨТӘСЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төтәсләү**. *Сугыш төтене белән бергә төтәсләнгән --- бу яшь егет [һәлак булды].* Г.Бәширов

2) Сөремләнү, корымлану, сөрем белән капланү. *[Танклар] өр-яңалар. Пулемёт борыннары гына төтәсләнгән.* Ш.Рәкыйпов

**Төтәсләнә төшү** Бераз төтәсләнү

**Төтәсләнеп бетү** Бик каты төтәсләнү. *[Тасмалар] яңа чагында нинди төстә булганлыклары да беленмәслек дәрәҗәдә каралып, төтәсләнеп беткәннәр.* З.Бәшири

**Төтәсләнеп тору** Даими, әле, хәзерге вакытта төтәсләнү

**Төтәсләнеп утыру** *к.* **төтәсләнеп тору**. *Өчәүләшеп текә сырттан металл күлгә төшеләр дә, металл коймакларда аяклары тая-тая, төтәсләнеп утырган конуска таба юнәлделәр.* А.Толстой

**ТӨТӘСЛӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә төтен бөркү, аны төтен бөркеп ыслау. *Әгәр дә без бүген кара урмандагы йөзьяшәр карт агач куышында яшәгән бал бирүче умарта кортлары семьясын, куыштан төтәсләп алып, умарталыкка күчереп куйсак, ни җитте умартачы әле бу урман кыргыйларының гәүдә төзелешендә --- нинди дә булса аермаларны таба алмас.* Умарта кортлары

2) Сөремләү, корымлау, сөрем чыгару. *Ни әйтсәң дә, шәһәрдәге шикелле, утырсаң таш, торсаң таш түгел, бензин исе белән дә төтәсләмиләр!* Г.Бәширов // Берәр нәрсәне сөрем, корым белән каплау. *Аның җитәкчелегендәге РСУ --- Бауман урамын күп мәртәбәләр төтәсләде.* Социалистик Татарстан

3) *этн. к.* **төсләү** (*2 мәгъ.*). *Җен кагылган татардан яки татар хатынынынан җенне куып чыгару өчен, аларны күкерт яндырып, шуның төтене белән төтәслиләр.* К.Насыйри. *Аннары, артыш яндырып, өй эчендәге почмакларны, абзар-кураларны төтәсләделәр, күздән кереп калган явыз ияләрне куалап чыгардылар [алар].* Н.Фәттах

4) *сөйл.* Бик күп төтен чыгарып (тәмәке, папирос) тарту. *[Егет] иренеп кенә папирос төтәсләргә тотынды.* Н.Фәттах

5) *күч.* Кискен чаралар куллану. *Буржуй холуйларын барлык ярыклардан әллә кайчан төтәсләп куарга вакыт!* К.Нәҗми

6) *күч.* Тузан сыман бик вак булып яву, пыску (яңгыр тур.). *Яңгыр төтәсләү*

**Төтәсли башлау** Төтәсләргә тотыну. *Качып-посып төпчек тартуның ләззәте беткәч, олылар алдында да оялмыйча, беркемнән дә курыкмыйча, хуш исле папирос төтәсли башлады [ул].* Н.Фәттах. *Ул арада карчыклар бүлмәне төтәсли башладылар.* Г.Гыйльманов

**Төтәсли төшү** Бераз төтәсләү

**Төтәсләп алу** Тиз генә төтәсләү. *Булмаса, бер төтәсләп алыйк, сусын басылыр.* Ә.Еники

**Төтәсләп бетү** Бик нык төтәсләү. *Ике йөз елдан бирле яна-яна тәмам төтәсләп беткән учакта коры чыбык-чабык чытырдый ---.* А.Толстой

**Төтәсләп йөрү** Бөтен җирне төтәсләү. *Разия, гуд агачын яндырып, урынҗирне төтәсләп йөри.* М.Фәйзи

**Төтәсләп тору** Озак вакыт яисә даими төтәсләү; әле, хәзер төтәсләү. *Атналар буе көне-төне вак иләктән*

*иләгәндәй төтәсләп торып үзәккә үткән --- бетмәс-төкәнмәс көзге яңгырлар туктаган.* Г.Бәширов. *Кулларына алар янып, төтәсләп торган артыш, миләш, юкә, шомырт агачлары тотканнар иде.* Н.Фәттах

**Төтәсләп утыру** *к.* **төтәсләп тору**. *Хәбәрдар булыгыз: курсыбыз – нордвест-вест, иңлек һәм озынлык (фәләнфәлән), горизонтта Везувий төтәсләп утыра.* А.Толстой

**Төтәсләп чыгу** Булган берсен төтәсләү. *«Ихлас» төркеме җитәкчесе Рәйхана Суфиянова, Сәкинә нәнәсеннән калган күзле мәшкәк белән, эш башлар алдыннан, кызларның куллары талмасын, күз тимәсен дип, төтәсләп чыкты.* Кызыл таң

**Төтәсләп яту** *сөйл. к.* **төтәсләп тору**. *Анилин компаниясенең төтәсләп яткан завод хәрабәләре өстеннән «Анилин Роллинг» әнә шулай атлап килә иде.* А.Толстой

**ТӨТӘТКЕЧ** *и.* 1) Кечкенә генә күрегенә басып, гадәттә бал кортларына төтен өрдерә торган корал; төтәсләвеч. *Монда нарат тактадан эшләнгән хуш исле рамнар саклый торган озын сандык, тәрәзә төпләрендә китаплар, сары стеналарда төтәткеч, корт тубаллары, битлекләр.* М.Мәһдиев. *Җизни, йөзеңә битлек кимичә, кулыңа төтәткеч тотмыйча, умарта алдында басып тора аласыңмы?* Ф.Яруллин

2) Балык, ит һ.б.ш. нәрсәләрне төтен белән ыслау өчен махсус җайланма. *Балыкның яртысын, ысларга дип, төтәткечкә элдем.* Ә.Камал

**ТӨТӘТҮ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәне пыскыту, төтенләп яндыру. *Сарсак Умгадан Гаврила – кайчан карама төрепкә төтәтеп, үз алдына гына карап йөрүче җирән сакаллы удмурт ---.* Г.Ахунов. *Күзе тигән кешенең берәр чүпрәген урлап кайталар да, утта төтәтеп, күз тигән кеше белән юрган астында каплап тоталар.* Татар мифлары

2) *куч.* Тәмәке тарту. *Өйдә балалар, ә син махра төтәтәсең, Габдуллаҗан абый.* А.Гыйләҗев. *Аңа инде байлар төсе кергән, ул, кырын ята төшеп, кыйбатлы папирос төтәтә.* З.Фәтхетдинов. *Олы кыя бераз тәмәкесен төтәткәч, ашыкмый гына сүз башлады.* И.Хуҗин

**Төтәтә башлау** Төтәтергә тотыну. *Аштан соң, кайсы кайда сузылып, тәмәке төтәтә башладылар.* Ш.Камал. *Сеңлесенең сораулы карашына серле кыяфәт белән күз кысып, Шурик балконга чыгып басты, тәмәке төтәтә башлады.* Х.Ширмән

**Төтәтә бирү** Бернигә карамый төтәтү. *Болар эчкән арада, карт, трубкасын төтәтә биреп, арба тирәли әйләнеп чыкты.* З.Зәйнуллин. *Әйе, бернигә карамыйча, кара яндырып төтәтә бирәбез.* Татарстан яшьләре

**Төтәтә төшү** Бераз төтәтү

**Төтәтеп алу** Тиз генә төтәтү. *Машинаны бушатып, такта яручылар төтәтеп алырга утырды гына, Ярмөхәммәт әрҗәне келәләргә ныгытып бетерде генә, пилорам янына баш инженер Гафуров, ГАИ капитаны Шәйхуллов килеп басты.* Р.Батулла. *Яшереп кенә тәмәке төтәтеп алуга да каршы түгел [ул].* Т.Галиуллин

**Төтәтеп җибәрү** Озакка сузмыйча төтәтү; төтәтә башлау. *Хөсәен янчыгын алып суза: «Төтәтеп җибәрәсеңме?»* М.Фәйзи. *Төребкәсенә тәмәке тутырды, аннан ашыкмый гына төтәтеп җибәрде ул.* Р.Мөхәммәдиев

**Төтәтеп тору** Хәзер, әле төтәтү; әледән-әле, һәрвакыт төтәтү. *Ул коридорда папирос төтәтеп торганда, директор аны үзенә чакырып алды.* Х.Камалов. *Өченчесе – хәрби киемдәгесе – читкәрәк тайпылып, тәмәке төтәтеп тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Төтәтеп утыру** *сөйл.* Хәзерге вакытта төтәтү. *Кирпеч суга белә ләбаса, нәрсәгә учак төтәтеп утырырга?* Г.Якупова

**ТӨТӘТҮ** II *ф. диал. к.* **төткәзү**. *Тишек иләк кебек [өйнең] стеналары, ягып кына төтәтә торган түгел.* Г.Ахунов

**ТӨТӘ́Ү** *ф.* l) Төтен чыгару, төтенләү. *Ул икенче бәйләмне әзерләгән арада, бая җиргә чәчелгән чыбыклар янып бетте, алар төшкән урыннарда ылыс төтәде, борынга тәмле ис үрләде.* А.Гыйләҗев. *Керогазда җылытыла торган сыекчаның савыттан ташып чыгуына юл куярга ярамый, чөнки керогаздан ялкын чыга, һәм ул төти.* Файдалы киңәшләр

2) Корым, сөрем чыгару, сөремләү. *Ил өстендә кара сугыш сөреме төтәгәндә, шәхси кайгы-хәсрәтеңне исәпкә дә алмыйсың.* А.Хәсәнов

3) Ялкынланмыйча, акрын гына төтен чыгару, пыску. *Берәүнең утыны ут бөркер, берәүнең утыны корыга төтәр.* Мәкаль

4) Төтен яки томан кебек булып тору, томанлану. *Абдулка шул югарылыкка, анда төтәгән Киек Каз Юлына күзен текәде.* К.Нәҗми. *Бүлмәсендәге әйберләр, тәрәзәләр рәшә эчендәге кебек кыеш-мыеш килеп төтәделәр дә юкка чыктылар.* Ф.Садриев

5) Тузан кебек бик вак булу, пыскып яву (яңгыр тур.). *Төтәп яуган вак яңгыр астында, почта самолётына утырып, Бөгелмәгә очтым.* Г.Ахунов. *Төтәп кенә яуган яңырдан түбә ышыкларына яшеренеп торасы юк.* Дөньяда ниләр бар

**Төтәп алу** Берара төтәү

**Төтәп бетү** Бик нык төтәү. *Мичне кабызып җибәрә алмый интектем, төтәп бетте*

**Төтәп тору** Хәзер, әле төтәү; билгеле бер вакыт төтәү. *Алда елга, алда күпер, алда зур авыл, Фашистлар яндыра аны: Төтәп тора ул.* Ф.Кәрим. *Оператив төркем килеп кергәндә, бүлмәдә берәү дә юк, уң як стена буендагы квадрат өстәл өстендә керосин лампасы гына төтәп тора иде.* Т.Әйди

**Төтәп утыру** *сөйл. к.* **төтәп тору**. *[Өйнең] түбәсе, тәрәзәсе бар, хәтта миче дә төтәп утыра.* А.Гыйләҗев. *[Нәфисә] сукыр лампа гына төтәп утырган ярым караңгы өйалды аркылы аш өенә чыкты.* Г.Бәширов

**Төтәп яту** *сөйл. к.* **төтәп тору**. *Ул, килеп, төтәп яткан учак янында төтенгә тончыгып аңын югалткан Газдалны танып ала.* К.Акбаш. *Тәрәзәләре ватык, ишекләре ачык, эчтәге әйберләре таланган, урамда трамвайлар аударылган, китаплар өеме төтәп ята, кәгазьләр очып йөри: мәхшәр.* Ватаным Татарстан

**Төти башлау** Төтәргә тотыну

**ТӨТӘЧ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан яз көне ялтыравыклы сары

чәчәк ата торган үлән үсемлек; кишер үләне; *русчасы:* **чистяк**. *Төтәч дип аталган чүп үлән безнең Татарстанда бик күп очрый.* М.Корбангалиев. *Фумар кислотасы төтәч (дымянка) үләнендә, күп кенә гөмбәләрдә (грибы) күзәтелә, алкалоидлар белән суда яхшы эрүчән тозлар барлыкка китерә.* Агулы үсемлекләр

**ТӨТӘ́ЧЧӘЛӘР** *и. бот.* Җимешләре тартмачык рәвешендә булган сөтчел сыекчалы ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. *Төтәччәләр (дымянковые): мөгезле мәк үләне (мачок рогатый), урта сәрдәнә (хохлатка средняя), дарулы төтәч (дымянка лекарственная).* Агулы үсемлекләр

**ТӨТЕК** *и. сир.* Төтен чыгарып яна торган пыяла куыксыз лампа. *[Хафиз] снаряд гильзасыннан ясалган төтеккә ут кабызды.* Ялкын

**ТӨТЕН** *и.* 1) Берәр нәрсә янганда чыга торган аксыл зәңгәр, каралҗым һ.б. төстәге газ. *Ә моржадан нәзек кенә булып сузылган төтен күк караңгылыгына кереп югала.* Ф.Кәрим. --- *Бүлмә тәмәке төтене белән тулган, һәм шул төтен эчендә унлап кеше ду килеп сөйләшеп утыралар иде.* В.Нуруллин

2) Сизелер-сизелмәс кенә күренә торган газ. *Бу төтен – вак кына аммоний хлориды кристаллы.* Неорганик химия

3) Махсус җайланмалардан якынтирәдәге объектларны дошманнан яшерү өчен чыгарыла торган болыт, куе газ. *– Төтен шашкаларын кабызып, суга ташла! – дип команда бирә Заһидуллин.* Г.Әпсәләмов

4) *тар.* Авылдагы йорт, хуҗалык саны. *Ул чагында бистә йөз егерме төтеннән артмагандыр.* К.Нәҗми. *Бер көнне төтен налогы җыючы Исмәгыйль түрә килеп керде.* Казан утлары

5) *күч.* Ялган хәбәр, сүз. *Мондый коткы дошман ягыннан, Колак чыгара мондый төтенне ---.* Ф.Кәрим

6) *күч.* Берәр нәрсәне әйтүче, сөйләүче кеше; чыганак. *[Нәсимә:] Бүләге нәрсәдер бит әле, Мәйсәрә, әйеме? [Нурия:] Төтене бу яктан икән (Мәйсәрәне күрсәтә).* К.Тинчурин

7) *күч.* Берәр нәрсәнең куркыныч билгесе, чагылышы. *Әх, куркак җан, сугыш төтененнән Котың чыгып, артка качтың син.* Ш.Мөдәррис

◊ **Төтен булу** 1) *к.* **төтен булып очу**. *Ахырда бер көн Китте өстән кара төн, Залим патша тәхетләре Янып булдылар төтен.* Г.Камал; 2) Нык исерү. *Эчеп төтен булган карт кыз күзен дә ача алмый иде.* Н.Гыйматдинова. **Төтен булып очу** 1) Бөтенләй юкка чыгу, эзсез югалу. *Аннары авыл кешеләренең абзар-куралары, мунча-келәтләре төтен булып күккә оча башлады.* Г.Гыйльманов; 2) Дәрәҗә төшү. **Төтенгә чәчелү** Төтен сулап тончыгу. **Төтене дөрес** Дөрес сөйләүче. *Моны ишеткәч, Наилә күтәрелеп бәрелде: төтене дөрес иде бүген хатынның!* А.Гыйләҗев. **Төтене йөрү** Берәр нәрсәне аңларлык, белерлек дәрәҗәдә булу, берәр нәрсәдән хәбәрдар булу. *[Китапларның] икесеннән дә бернәрсә аңлар хәл юк. Урысчасына төтен йөрми, татарчасына язучының үзенең төтене йөрмәгән.* М.Фәйзи. **Төтене куе чыгу** Дус яшәү. *Электән үк әтәче дә күкәй сала торган ике нигез бергә кушылгач, төтеннәре куе чыга башлады боларның.* Ш.Рәкыйпов. **Төтене кыек** Ялган сөйләүче, дөреслекне яшерүче. **Төтене кыек чыгу** Дөрес сөйләмәү, хәйләләү, ялганлау. **Төтене туры** Дөресен сөйләүче, турыдан-туры әйтүче. **Төтене туры (дөрес) чыгу (йөрү)** Дөрес сөйләү, турыдан-туры әйтү; дөреслеккә туры килү. *Хәйбуш бу сүзләрне ярым курку, ярым кызыксыну аралаш тыңлап торды да: «Һе! Төтене туры чыга түгелме соң моның...» – [диде].* К.Нәҗми. **Төтен җибәрү** Берәр нәрсә турында кемдә дә булса ялгыш фикер тудыру; алдау. *Мәсәлән, һәрбер мещан төтен җибәрергә, мактанырга ярата.* М.Зәкиев. **Төтен йоту** *к.* **төтен чыгару** *(1 мәгъ.) Үзе дә гарык инде ул төтен йотып җан тынычлыгы табарга омтылудан.* Ә.Моталлапов. **Төтен кушу** Дөрес булмаган мәгълүмат кушу; ялганлау; арттыру. *Һайгануш чукындыру турында төтен кушып сөйләде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Төтеннән котылам дип утка төшү** Бер авыр хәлдән чыгып икенчесенә эләгү. **Төтеннең кайсы якка авышканын шәйләү** Мәсьәләнең асылын аңлау. *[Мәктәптә] төтеннең кайсы якка авышканын шәйләмиләр дип уйлыйсыз.* Совет әдәбияты. **Төтен очыру** 1) Тәмәке тарту; 2) *к.* **күзгә төтен җибәрү**. **Төтен санау** 1) Юк-бар, файдасыз эш белән шөгыльләнү; 2) Гайбәт сөйләү. *Сезнекеләр урамга төтен санарга чыгып киттеләр.* Х.Садри. **Төтен тавы** Тормышка ашмаячак зур планнар, вәгъдәләр. **Төтен тавы тоттыру** Бик каты алдау. **Төтен чыгару** 1) Тәмәке тарту. *Дөрес, тәмәкене Гаяз да, мин дә чынлап тартмый идек, тарту дигәнебез төтен чыгару гына иде.* М.Әмир; 2) Бушка гомер уздыру. *Без дә, яшибез дип, төтен чыгарып йөрибез икән, селкенеп.* А.Гыйләҗев; 3) Үз йортын, үз хуҗалыгын алып бару. *Менә шулай итә-итә, ниһаять, үзебезнеке дигән куыш та булды... Үз башыбызга төтен чыгара башладык.* И.Салахов. **Төтен чыгу** Эш бик күп булу. **Төтен чыкканчы** Бик күп, бик каты (эш эшләү тур.). **Төтен эчү** *иск.* Тәмәке тарту. *Ут кабызмый ул, төтен эчкәндә, иптәштән элек; Әүвәле аңгар суза: икрам вә хөрмәт күрсәтә.* Г.Тукай

**ТӨТЕНЛӘГЕЧ** *и. к.* **төтәсләгеч**. *Бакча үсемлекләренә төтен җибәргәндә, аларны полиэтелен белән каплап, умартачылар куллана торган төтенләгечне 5–10 минутка плёнка астына тыгып эшләтеп алырга кирәк ---.* Серле календарь

**ТӨТЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) Эченә төтен тулу

2) Ыслану; сөремләнү, корымлану. *Моржаларны агартып тору мәҗбүри, чөнки каралган, төтенләнгән урыннарына карап, алардагы ярыкларны бетерүе җиңелрәк.* Биектау хәбәрләре

**Төтенләнә төшү** Бераз төтенләнү

**Төтенләнеп китү** Көтмәгәндә төтенләнү

**Төтенләнеп тору** Даими, әледән-әле төтенләнү

**ТӨТЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Янып, пыскып төтен чыгару. *Көйгән кәгазь исе дә шикелле, чүпрәк төтенләгән дә кебек.* Г.Бәширов. *Үзем һаман аксак-туксак әле, Эчтә кисәү һаман төтенли.* Ш.Маннур

2) Төтен белән тутыру. *Бүлмәне тәмәке белән төтенләү*

3) Атканнан соң утлы коралдан төтен чыгу. *Кыр казлары елап кузгалдылар, Төтенләде мылтык көпшәсе.* В.Фатыйхов. *Бушаган гильзалар, төтенләп, аяк астына тәгәрәде.* Х.Ибраһим

4) *сөйл.* Тәмәке тарту. *Алар нәрсә турындадыр иренеп кенә сөйләшеп утыралар һәм юан итеп төргән самосадкалары белән мәрхәмәтсез төтенлиләр.* А.Шамов

**Төтенләп алу** Бераз, кыска вакыт эчендә төтенләү. *– Юк инде, сентябрьдә алай кыланып булмый, – диде ул, папирос тартмасын чыгарды, – төтенләп алмыйбызмы?* И.Гази. *Метрода берниндиянгын да чыкмады, бер вагонда электр чыбыгы төтенләп алды.* Татарстан яшьләре

**Төтенләп бетү** Бик каты төтенләү

**Төтенләп тору** Даими яки берникадәр вакыт төтенләү; әле, хәзер төтенләү. *Аның күз алдына ашлык һәм корал төягән фронтка чабучы поездлар, төтенләп торган заводлар килә.* Г.Бәширов. *Сәйфулла бер Миңлебайга, бер төтенләп торган чокырга карап алды һәм һава дулкыныннан ауган «максим»ны торгыза башлады.* З.Зәйнуллин

**Төтенләп утыру** *к.* **төтенләп тору**. *Кырау көйдергән бәрәңге басуларын, юантык кибәннәрне, майлы таба исе катыш төтенләп утырган морҗаларны, кызгылт-чуар урманнарны, киртә буена арканлаган ялкау, йокымсыраган бозауларны, су буендагы кара мунчаларны коточкыч биеклектән карап, торналар китә.* М.Мәһдиев. *Әлеге вулкан инде 2009 елның маеннан бирле төтенләп утырса да, моңа кадәр аның ныклап «кызып киткәне» булмаган.* Татарстан яшьләре

**Төтенләп яту** *к.* **төтенләп тору**. *Төтенләп яткан шәһәр-авыллар, җир өстенә сибелгән яңа каберләр – болар һәммәсе дә күз алдында әле ---.* М.Галәү. *Артта, шактый еракта, кап-кара таш-тузан эчендә, Магнитка төтенләп ята иде.* Ф.Бәйрәмова

**Төтенли башлау** Төтенләргә тотыну. *[Хуҗа] газетадан «кәҗә аягы» ясап төтенли башлады.* Н.Дәүли. *Көтмәгәндә күптән сүнгән крематорий мичләре төтенли башлады.* Г.Әпсәләмов

**ТӨТЕНЛЕ** *с.* 1) Төтенләп торган. *Китегез, китегез күз алдыннан --- әсир тулы үлем бараклары, укшыткыч төтенле зәһәр крематорийлар!..* Ш.Рәкыйпов. *Ул кайткач, дәфтәрләр дә, кызыл төтенле танклар да онытылды.* Д.Аппакова

2) Төтен белән пычранган, төтен катнашкан. *Минем бер кабар җирем дә калмады: суыгыз исле, һавагыз төтенле, юлларыгызны сумала каплаган...* К.Тимбикова. --- *Казандагы бүгенге төтенле һаваны иснәү көненә ике тартма тәмәке тартып бетерүгә тиң икән.* Татарстан яшьләре. *Киңәш-табыш иткәч, алар төтенле, тузанлы шәһәрдән туган авылларына кайтырга булалар.* Яңа тормыш // Төтен тулган. *Бу төтенле, буталчык халыклы бүлмәдән тизрәк таярга әйбәт сылтау булып төште.* Г.Ибраһимов

3) Төтен исе сеңдерелгән, төтен белән ысланган. --- *Әйдәгез урманга, төтенле ит ашарга!* А.Гыйләҗев. *Һәрхәлдә, төтенле ризыкның түбән татып караган инглиз журналистлары шулай дип тәкрарлый.* Ватаным Татарстан

4) *махс.* Селитра, күкерт һәм агач күмере катнашмасыннан торган. *Төтенле дары*

**ТӨТЕ́Н САЛУ** *ф.* 1) Үсемлекләрне кыраудан саклау өчен, төтенләп чыга торган нәрсәгә ут ягу

2) Җәйге челләдә атларны кигәвен һәм чебеннән аралау, корт караганда, аларны умартадан куу, баздан газ чыгару өчен, куе төтен чыгарып ут ягу. *Яз көне, базга кар салу вакыты җиткәч, абыйсы Илгизәр базга төтен сала.* Биектау хәбәрләре

**ТӨТЕНСЕЗ** *с.* **1.** Төтене булмаган; төтен чыгармый торган. *Коръән мәгълүматлары буенча, җеннәр төтенсез уттан барлыкка китерелгәннәр ---.* Ф.Урманче

**2.** *рәв. мәгъ.* Төтен чыгармыйча. *[Нобель А.Б.] төтенсез шартлый торган дарының составын эшләгән.* Химия. *Өйгә керерлек түгел, төтенсез яна.* Сөембикә

◊ **Төтенсез авыл** Зират, каберлек. *Төтенсез авылга хат керми.* Мәкаль. *Күрәсең, миңа төтенсез авылга китәр вакыт җитәдер инде.* Г.Бәширов. *Бу тыныч төтенсез авылга тагы кемнәрдер күчкән...* Р.Габделхакова

**ТӨТЕН-СӨРЕМ** *җый. и.* Төтен һәм сөрем, бик кара төтен. *Т-34 танкы, чит җирнең соргылт-комсу туфрагын чылбыр табаны белән изеп, төтен-сөрем ерып, зур тизлек белән бара иде.* М.Маликова

**ТӨТЕНСУ** *с.* 1) Төтенгә охшаш, төтен сыман. *Ел тәүлегендә бертуктаусыз диярлек исеп торган ачы җилләр, төтенсу томан, тузан төсле вак яңгыр, җепшек кар, кислород кытлыгы, авыр эш – болар барысы да көннәр, айлар үтү белән кешене шулхәтле изә, миңгерәүләтә: ул яшәүгә өмете тәмам өзелгән, дәрте бөтенләй сүнгән бер җан иясенә әверелә.* Г.Әпсәләмов. *Күл өсте төтенсу томан эчендә иде.* М.Галиев

2) Төтен төсендәге. *Аңа «Ролекс»ның зурлыгы, матур ялтыраган алтыны, төтенсу платина циферблаты, төнлә яктырып торучы телләре һәм, әлбәттә, үтә төгәл йөрүе ошый иде.* Р.Мирхәйдәров

**ТӨТЕНСУЛАНУ** *ф.* Төтен төсенә керү, төтенгә охшаш булып китү. *Пеҹәнгә чыгар алдыннан, төтенсуланган урманга барлык җиһазлар белән төшергә булдык.* М.Кәрим

**ТӨТЕН-ТУЗАН** *җый. и.* Төтен һәм тузан. *Төтен-тузан күтәрелде, корбаннарны гына чамалап булмый.* Р.Сәгъди

**ТӨТКӘЗҮ** *ф.* Берәр кешегә яки нәрсәгә җиткерү (эш, материал, азык тур.). *– Уф Алла! – Надзиратель гыжылдап сулап, ишекне ачып җибәрде. – Шикәр капчыгы төткәзеп булмый.* И.Салахов. *Әни юып та, тегеп тә төткәзә алмый.* Х.Камалов

**Төткәзеп бетерү** Тиешле дәрәҗәдә төткәзү. *Ахырында ничек төткәзеп бетермәк кирәк?* Ә.Гаффар

**Төткәзеп җиткерү** *к.* **төткәзеп бетерү**. *Выжимной подшипник төткәзеп җиткерер хәл юк.* Х.Камалов

**ТӨТКӘРҮ** *ф. к.* **төткәзү**. *Шул кичтә Гариф, төткәрү өчен алынган ак җәймә өстенә утырып, үз хикәясен*

*сөйләргә тотынды.* А.Расих. *Барлыюклы ике йөк печәнне шушыңарчы төткәргәнгә рәхмәт әйт!* В.Нуруллин

**ТӨТРӘ** *и. диал.* **1.** Төтен, тузан кебек сизелер-сизелмәс кенә булган вак яңгыр һәм һавада шуннан хасил булган тоныклык, пәрдә. *Төтрә төшү*

**2.** *с. мәгъ.* Сизелер-сизелмәс, вак (яңгыр тур.). *Төтрә яңгыр барганлыкка карамастан, ул аның артыннан урамга йөгереп чыкты.* Ф.Хөсни

**ТӨТРӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **төтрәләү**

2) Күз алды томалану, юка элпә белән каплану. *Кинәт кенә тынлык җуялды. Бераз төтрәләнде күз алды.* Ф.Бурнаш

**Төтрәләнә төшү** Бераз төтрәләнү

**Төтрәләнеп китү** Кинәт төтрәләнү

**Төтрәләнеп тору** Күпмедер вакыт төтрәләнү

**ТӨТРӘЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **төтрәү**

**ТӨТРӘҮ** *ф. диал.* Төтрә яву һәм шуның белән һава бераз томанлану

**ТӨТСЕНҮ** *ф. диал.* 1) Сизү. *Авыртуны төтсенү*

2) Калтырану, туңу, өшү

3) Көтелмәгән сүз-хәбәр, хәрәкәт һ.б.ш.дан бик нык тәэсирләнү. *Ишеткән яңалыктан төтсенү*

**Төтсенә төшү** Бераз төтсенү

**Төтсенеп алу** Кыска гына вакытка төтсенү

**Төтсенеп җибәрү** Аз гына төтсенү

**Төтсенеп тору** Күпмедер вакыт төтсенү; хәзер, әле төтсенү. *Тормышта бик сирәк зарлана торган әнисенең бөтенләй чит-ят кешегә, җитмәсә пыялачыга, үз нужасын сөйләвен ишетеп үртәлгән Һади бер читкәрәк китте һәм еракта төтсенеп торган кешене күрде, әлбәттә, бу Маһирә иде.* А.Гыйләҗев

**ТӨТТЕРҮ** *ф. диал. к.* **төткәзү**

**ТӨТҮ** *ф.* Җитү, җитәрлек булу (аш, ашамлык, акча һ.б.ш. тур.). *Эшмәкәргә эш төтми.* Мәкаль. *Уңган кулга эш төтми.* Мәкаль. *Боларның һәммәсен ак кәгазьгә күчерим дисәң, каләм өчен җирдәге агач төтмәс, кара өчен дәрья җитмәс шикелле.* Ә.Гаффар

**Төтә төшү** Бераз төтү

**Төтеп бетү** *к.* Тулысынча төтү

**ТӨФ** *иярт. к.* **тфү**. *Төф-төф! Авыруы бетсен-китсен, җилгә очсын!..* В.Нуруллин

**ТӨФЕЛДӘТҮ** *ф.* Төф-төф итеп төкерү

**Төфелдәтеп кую** Кинәт төфелдәтү

**Төфелдәтеп тору** Әледән-әле төфелдәтү

**ТӨФЕЛДӘ́Ү** *ф. сөйл. сир.* Төкерү

**Төфелдәп кую** Кинәт төфелдәү

**Төфелдәп тору** Әледән-әле төфелдәү

**ТӨҺМӘТ** *и. гар. иск.* Берәүгә ягылган яла, яман гаеп. *Кыскасы, театр хакында хыялга да килмәгән ялганнар, төһмәтләр берлән халыкның башын катыралар иде.* Г.Исхакый. *Фуад өстеннән ялган төһмәтләр (ялалар, гаепләр) ясап, көтепханәдән чыгуына да сәбәп булды.* Х.Миңнегулов

**ТӨҺМӘ́Т ИТҮ** *ф. иск.* Гаеп ягу, берәр төрле эштә гаепләү

**ТӨҺМӘ́Т КЫЛУ** *ф. иск. к.* **төһмәт итү**. *Хатын һәрзаман, тутый сүзе белән «миңа төһмәт кыйлдың» дип, хуҗага үпкә тотар иде.* К.Насыйри

**ТӨЧ** *иярт.* Теш арасыннан нечкә итеп төкергәндә чыккан авазны белдерә

**ТӨЧЕ** I *с.***1.** 1) Тозсыз. *Ике капкачлы төче сулык моллюсклары --- 10–25 мм озынлыкта.* Биология: хайваннар. *Һәр киловатт егәрлеккә бер куб метр төче су алырга мөмкин!* Химиянең киләчәге

2) Тозы аз булганга яки бөтенләй булмаганга, үзенчәлекле тәмен югалткан. *Һәрвакыт бертөрле, төче, тәмсез азык ашау аппетит кимүгә һәм ашказаны бозылуга китерә.* Робинзон эзләреннән // Тоз, әче тәмләткечләр салып әзерләнгән: *киресе*: **әче**. *Бу бер дә йорт сырасына охшамый ла: бер яктан караганда, ачы, икенче яктан караганда, төче, әллә нинди әчкелтем-төчкелтем тәмнәр килә.* Г.Камал

3) Чүпрә салмыйча әзерләнгән, әчетелмәгән (камыр ашлары тур.). *Пешекчеләр мичне караган иде, бер төче күмәч белән бер үрдәк юк.* Әкият. *Чатыр-чотыр май кыздыруга, өйгә җәелгән тәмле искә карап хөкем йөрткәндә, төче коймакның шәп булуы шиксез иде.* Ф.Хөсни. *Төче прәннекләрне иттарткычтан чыгарырга һәм сода кушарга [кирәк].* Серле календарь

4) Шикәрле, баллы, татлы. *Ул кадәр баллы нәрсә булгач, бик төче нәрсә булып, безне бөтенләй үтләтеп бетермәсә ярар иде дип куркам.* Г.Камал

5) Күңелгә авыр, күңелне болгата торган (ис тур.). *Бөтен бүлмәләргә әллә нинди дару исе – төче, борынны ярып керә торган бер ис тулган...* Г.Исхакый. *Ландышлар нечкә сабакларына кечкенә ак кыңгырауларын тезгән, алардан бөтен урманга куе төче ис тарала.* К.Тәхау

6) *күч.* Күңел болгатырлык юмакай. *«Тәрҗеман» гәзитәсенең һәр нумирында мәгариф вә тәрәккъые милләт өчен чаралар эзләү лязем идеке, мәгарифсез милләт – җансыз кеше кеби улдыгы ачык-ачык иттереп, кайвакыт бик ачы, кайвакыт төче гыйбарәләр берлән мәкаләләр күренә башлады.* Г.Исхакый. *Мин бу хәтле ясалма һәм төче сүзләр ишетергә тиешмени соң?* Н.Гыйматдинова

7) *күч.* Үтә сентименталь, чамасыз назлы. *Моңа кадәр басылып килгән, җиңел укылып та тиз онытыла барган --- кайбер төче мәхәббәт романнарыннан аермалы буларак, [«Ханымсолтаным»] конкрет шартларга бәйле, тормышчан әсәр.* Л.Ихсанова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чүпрә салмыйча әзерләнгән камыр. *Чәкелтәк төчедән була.* Ф.Баязитова

2) Тормыш итү өчен жиңеллек; бертөрле шатлык, рәхәтлек. *Әнә Вәли бай: «Ярый, туган, – ди, – дөньяның ачысы да булды, төчесе дә булды».* Г.Ибраһимов

3) Шикәрле, татлы ашамлык. *Куй, куй, әчесеннән, төчесеннән мул итеп куй.* Т.Гыйззәт

4) *диал. к.* **төчлегән**

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Юмакай итеп, ялагайланып. *Хатыңны син бик нечкә, әйтергә яраса, бик төче язгансың.* Г.Кутуй. *Ишектән песи шикелле генә кердем дә бик төче итеп исәнләштем.* Т.Нәҗмиев. *Аның каршысында, берни булмагандай, тагын баягыча төче елмаеп, Сәйфи басып тора.* Г.Бәширов

2) **төчегә** Чүпрә салмыйча, әчетмичә. *Төчегә пешерү*

◊ **Төче коймак** 1) Күп һәм тәмле ашаучы кеше. *Минем ирем аклар белән*

*сугышканда үлде, ярлылыгым зур, ул төче коймакның [мулланың] корсагын тутырырга миннән иген сорау оят түгелме?* Г.Толымбай; 2) Артык ярарга тырышучы, ялагай, юмакай, тиз туйдыра торган кеше. *Я, төче коймак, дөресен әйтәсеңме, юкмы?* Ж.Вәлиди. **Төче корсак** Төче, татлы әйбер генә ашарга яратучы кеше. **Төче күмәч** *к.* **төче коймак**. *[Егет] авылның пешеп җитмәгән төче күмәче түгел микән?* Г.Мөхәммәтшин. **Төче тел(ле)** Бик йомшак, мактап сөйләшүче; юмакай кеше. *Ачы тел – хак агайда, Төче тел – ялагайда: Төче тел бик кирәк була Тәлинкә ялаганда.* Н.Арсланов. **Төче телләнү** *к.* **төче теллеләнү**. *Самавыр кайнап чыкканны көткән арада, Габделхәлим шактый ук төче телләнеп сөйләп алып китте.* Г.Ахунов. – *Букетың бик матур, миңа бүләк ит әле, Гөлфия, – диде Гамир. Өмет итми инде, төче телләнә генә.* Р.Айзатуллин. **Төче теллеләнү** Ярарга тырышып, бик йомшак итеп, мактап сөйләү, юмакайлану. *Миңсылу ире тирәсендә төче теллеләнеп: «Сиңа әйтәм, әллә бүген аш тәмсез булганмы? Нигә, җаным, ашамыйсың?» – [ди].* К.Тинчурин. **Төче теллелек** Юмакайлык. *Без дә бер кешедәй дус булыйк, Алла яратсын өчен; Эрелек, төче теллелекне ташлыйк, Алла яратсын өчен.* Г.Тукай

**ТӨЧЕ** II *и.* 1) Кызгылт көрән, алсу төстә тәңгә, биткә (гадәттә авыз, борын тирәләренә) чыга һәм кутырлана торган тире туберкулёзы; *русчасы:* **золотуха**

2) *иск.* Сифилис

**ТӨЧЕ́ АВЫРУЫ** *и. к.* **төче** II (*1 мәгъ.*). *Дию борычының тамыры төче авыруына (золотуха) каршы кулланыла.* Робинзон эзләреннән

**ТӨЧЕГӘН** *и. диал. к.* **төчлегән**

**ТӨЧЕГӘ́Н АТНАСЫ** *и. этн.* 15–20 июньнәрдә үткәрелә торган җыен исеме

**ТӨЧЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Төче I (*1 мәгъ.*) хәлгә китерү, һәртөрле тозлардан арындыру. *Биохимия дә суны төчеләндерә.* Химиянең киләчәге. --- *Кариб диңгезе утрауларында диңгез суын төчеләндерү ысулы кулланыла ---.* География. *Кайбер илләрдә диңгез суыннан химик матдәләр алалар һәм суны төчеләндерәләр.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) *күч.* Мактау сүзләре кыстыру, үтә ягымлы итү. *Хәбир, юри тавышын төчеләндереп, түтигә текәлде.* А.Әхмәтгалиева

**Төчеләндерә башлау** Төчеләндерергә тотыну

**Төчеләндерә төшү** Бераз төчеләндерү

**Төчеләндереп алу** Тиз генә төчеләндерү

**Төчеләндереп бетерү** Бик төче итү, тәмам төчеләндерү

**Төчеләндереп җибәрү** Кинәт төчеләндерү

**Төчеләндереп тору** Әледән-әле төчеләндерү

**ТӨЧЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Төче I (*1, 2 мәгъ.*) хәлгә килү. *Юл буе вагон ризыгы ашап күңел төчеләнгән иде, тозлы кыярны умырдык кына.* М.Мәһдиев. *Аларны [суүсемнәрне] яктыртылган бассейннарда үрчетәләр, ә инде су төчеләнгәч, суны аерып алалар.* Химиянең киләчәге. *Җәен ярга якын өлешендәге сулар боздан арчыла һәм елга суларыннан бик нык төчеләнә.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) *күч.* Ялагайлану, юмакайлану. – *Оркестр да яллый алмагансыз, – дигән булдым, озата килгән иптәшләремә төчеләнергә ирек бирмәскә тырышып ---.* Ф.Хөсни. *Чыкырдап торган авыл малае Фоатны тормышта тыңлап туймаслык, ә менә яза башласа – көязләнә, төчеләнә, кылана.* Т.Миңнуллин

3) *күч.* Сентиментальлеккә бирелү. *Табигать матурлыгы белән төчеләнү*

**Төчеләнә бару** Торган саен төчелек арту

**Төчеләнә башлау** Төчеләнергә тотыну. *Баш врачның артык төчеләнә башлавын күргән кунак аның сүзен бүлде ---.* М.Хәсәнов. *Әмма кайбер мәхәббәт шигырьләрендә шагыйрь артык төчеләнә башлый, сентименталь хисләргә бирелеп китә.* Р.Миңнуллин

**Төчеләнә төшү** Бераз төчеләнү. – *Исәнме-саумы, сөекле киленебез Сөембикә, – дип күреште Хөршидә бикә, бераз төчеләнә төшеп.* М.Хәбибуллин

**Төчеләнеп алу** Кыска вакыт аралыгында төчеләнү. *Әмма мәкалә авторлары бу язманың башында гына --- шулай төчеләнеп ала ---.* Безнең гәҗит

**Төчеләнеп бетү** Бик төче хәлгә килү

**Төчеләнеп китү** Кинәт төчеләнү. *Ипиең һәркем күңеленә хуш килерлек тәмле дә, йомшак та булсын өчен, камыр артык әчеләнеп тә, кирәгеннән артык төчеләнеп тә китәргә тиеш түгел.* Якты юл

**Төчеләнеп тору** Әледән-әле, даими, билгеле бер вакыт дәвамында төчеләнү. *Ләкин телевидениедә дип, төчеләнеп торасым килмәде.* М.Кәбиров. *Сыер савучылар үпкәләмәс дип уйлыйм, алар төчеләнеп тормыйлар бит.* Ватаным Татарстан

**Төчеләнеп утыру** *сөйл. к.* **төчеләнеп тору**. *Берсе белән дә төчеләнеп утырганым юк.* Ирек мәйданы

**ТӨЧЕЛЕК** *и.* 1) Төче (*1–4 мәгъ.*) булу. *[Кабак] төчелеге белән хәтта ачлы-туклы яшәгән кешене дә биздерә.* М.Әмир

2) *күч.* Юмакайлык, ялагайлык. *Аның йөзенә чыккан татлы төчелек белән бергә күзләренә чыккан серле хәйләкәрлекне күрүгә, Сәрви, беркадәр куркынып: «Ни булды, карт?» – дип сорады.* Ф.Әмирхан. *Күпләрне мин, бәлки, ошатмыймдыр. Төчелеге өчен.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ТӨЧЕ-МӨЧЕ** *с.* **1.** Төче һәм башка шундый тәмнәрдәге. *Гәрәй карлыган яфрагы, керән, тагын әллә нинди төче-мөче тәмнәр килеп торган кыярларга ябышты.* А.Гыйләҗев

**2.** *җый. и. мәгъ.* Һәртөрле татлы камыр ашлары. *Күрше өйне урап кына чыгасы иде югыйсә, юк, әйләнебрәк кайта [Кәримә]: газета-журнал киоскысына сугыла, төче-мөче, мороженый ларёкларына кагыла.* М.Хәбибуллин. *Барышлый кибетләргә кагыласы, малайларга әз-мәз төче-мөче аласы булыр...* А.Гыйләҗев

**ТӨЧЕНҮ** *ф. диал.* 1) Рәхәтләнү, ләззәтләнү

2) Төчеләнү, ярарга тырышу. *Я, төченмә әле. Күңелне болгатасың*

3) Тозлырак, әчкелтемрәк ашамлык теләү. *Хатын төченә, бәби көтәбез*

**Төченеп китү** Кинәт төченү. *Гәп куерды, карт кумый, атлар бара үзалдына, инде ул төченеп китә, борылып утыра каршына.* Ялт-йолт

**ТӨЧЕРҮ** *ф. диал.* Төчеләнү. *Тоз сипкәч, торма да төчерә.* Мәкаль

**ТӨЧЕТАМЫР** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан тугайларда һәм басуларда үсә, тамырлары ашказаны авыруларын дәвалауда кулланыла торган дару үләне; *русчасы:* **лакрица**. *Ак төчетамырны чәйнәү бик рәхәт булып тоелды.* М.Гафури. *Аларга [сирәк очрый торган үсемлекләргә] татар катраны, кыргый кашкарый, Вилькольмм глобуляриясе, төчетамыр, кукчәчәк --- кебек үсемлекләр керә.* Татарстан географиясе

**ТӨЧЕТОРМА** *и. бот.* Редиска. *Ачы торма, төчеторма, чөгендер дә кишер – Ходай бирсә, килешер!* Б.Камалов. *Кайбер яшелчәләр, мәсәлән, сельдерей, салат, брокколи, шпинат, төчеторма нитратларны зур күләмдә тупларга сәләтле.* Идел

**ТӨЧЕТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **төчү**. *Камыр төчетү*

2) Төче ис чыгару

3) *күч. сөйл.* Бик тәмләп йоклау. *Юлда ул бераз төчетте*

**Төчетә башлау** Төчетергә тотыну

**Төчетеп бетерү** Тәмам төчетү

**ТӨЧЕ́ УТЫ** *и. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан ланцетсыман яфраклы, вак сары чәчәкле, төче авыр исле үлән үсемлек (сабагындагы сары суын майга изеп, төче авыруына сөртәләр); эт тигәнәге; *русчасы:* **череда трёхраздельная**

**ТӨЧЕ́ ҮЛӘН** *и. бот. к.* **төче уты**. *Гади гөлҗимеш тамырын, гади барбарисны – икешәр өлеш, игүле кориандр һәм төче үләнне өчәр өлеш ваклаганнан соң, --- 10 минут кайнатып, ярты сәгатьтән сөзәргә.* Гаилә учагы

**ТӨЧЕЧИЯ** *и. бот.* Чия ыругыннан төче тәмле, түгәрәк сары, алсу, кызыл җимешләре чиягә охшаган җимеш агачы; шул агачның җимеше; *русчасы:* **черешня**. *Әфлисун янына төшләре алынган төчечияләрне салырга.* Серле календарь

**ТӨ́Ч ИТҮ** *ф.* Теш арасыннан нечкә генә итеп төкерү

**ТӨЧКЕЛТ** *с.* Төчкелтем. *Яз иде, тәрәзәдән яз җылысы белән күперенгән дымлы җир исе, тал бәпчекләренең төчкелт баллы исе бәреп тора иде.* Г.Бәширов

**ТӨЧКЕЛТЕМ** *с.* 1) Бераз төче булган. *Борыныма төчкелтем бер ис керде.* М.Әмир. *Бәрәңге җылы иде әле. Аның төчкелтем исе авыз суларын агыздырып борынга керде.* А.Расих

2) *күч.* Ярарга тырышучан, юмакай, артык назлы. --- *Анда [хатта] төчкелтем сүзләр шактый күп иде.* Г.Камал

**ТӨЧКЕРЕК** *и.* **1.** 1) Төчкерү һәм шул вакытта чыккан тавыш. *Дөрес сүзгә төчкерек.* Әйтем. *Исән чагында бик азындырдыгыз: һәр төчкерегенә «Ярьхәмекалла!» дип кенә тордыгыз.* Б.Камалов

2) *күч.* Яшьрәк буын, балалар. *[Гөлсем:] У-у, болар тегә кыр үрдәгенең төчкерекләреме?* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Юк кына, кечкенә генә. *Төчкерек кенә түрә дә уч тутырып каерып акча алып калырга, хәләлне дә ришвәт белән хәрәмләштерергә тырыша.* Ф.Яхин

**ТӨЧКЕРЕ́К УТЫ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан ак чәчәкле ланцетсыман яфраклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **чихотная трава**

**ТӨЧКЕРЕК ҮЛӘНЕ** *к.* **төчкерек уты**

**ТӨЧКЕРЕНҮ** I *ф.* 1) Кат-кат, берьюлы берничә тапкыр төчкерү. *Томау төшсә, салкын тисә, грипп эләктерсә, йөткылыгы һәм борынындагы нерв җепселләренең сизгерлеге күпкә арта, һәм кеше төчкеренә башлый.* Гаилә календаре

2) Үзалдына төчкерү. *Пошкырындым, төчкерендем, уңәчемә ут капкандай булды.* Б.Камалов

**Төчкеренә башлау** Төчкеренергә тотыну. *Ә тегеләр берсе өстенә икенчесе килеп каплаңдылар һәм, кабат күтәрелеп, үзләренең чүплеге өстендә Гыйфрит өермәсе булып болгандылар да, тузан-өрмә куптарганнан соң, үзләре дә шуннан тончыгып, төчкеренә башладылар.* Ф.Яхин

**Төчкеренеп алу** Бераз төчкеренү

**Төчкеренеп тору** Әледән-әле, беркавым төчкеренү. *Иснәгәндә, ютәлләгәндә, төчкеренеп торганда сөйләшмәгез, бәлки яулык илә авызыгызны каплагыз.* Р.Фәхретдин. *Керпе Сәлим дә зур гына чеметем тәмәке тузанын пошкыра-пошкыра борыны эченә суырды да беравык төчкеренеп торды.* М.Галәү

**ТӨЧКЕРЕНҮ** II *и.* Бик еш төчкерү белән характерлана торган физик халәт. *Ютәл яки төчкеренү башланса, халыкның рәхәтен бозмас өчен, мәҗлестән чыгып торыгыз.* Р.Фәхретдин

**ТӨЧКЕРТКЕЧ** *с.* Төчкертә торган. *Башта ул --- бозык күкәйләрне, банан кабыкларын, төчкерткеч борыч капларын бер күчкә җыйды.* Р.Вәли

**ТӨЧКЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **төчкерү** (*1–2 мәгъ.). Ашка салсаң – тәм кертә, Борынга салсаң – төчкертә.* Табышмак

2) *з.-сыз* Бертуктаусыз төчкерү. *Баш та авырта, хәл дә юк. Үзе тагын төчкертә дә йөткертә.* Н.Фәттах. *Төчкертә, сөякләрегез «ватыла» башласа, сезгә грипп үрмәләми микән?* Әтнә таңы

3) *күч.* Мылтык, пистолет һ.б.ш. ут коралыннан бер тапкыр ату. *[Мылтыкны] турылап, тегә [хыянәтчегә] берне төчкерттем.* Г.Әпсәләмов

4) *күч.* Кемнең дә булса кәефен бозу; куркыту, өркетү. *Ул кеше хәзер ире өчен елап утыра булыр; без аны юкка төчкертмик.* Ш.Камал

**Төчкертә башлау** Төчкертергә тотыну. *Исе борынга керсә төчкертә башлый, ди.* Ф.Яруллин. *Шуннан төчкертә башлый, борын эче йомшарып китә, томау бетә, сулыш алу иркенәя.* Ватаным Татарстан

**Төчкертеп алу** Бераз төчкертү

**Төчкертеп җибәрү** *к.* **төчкертеп кую**

**Төчкертеп кую** Кинәт төчкертү

**Төчкертеп тору** Әледән-әле төчкертү

**ТӨЧКЕРҮ** I *ф.* 1) Борын куышлыгын берәр нәрсә тынычсызлау яки кычыттырудан ихтыярсыз кискен сулыш чыгару. *Ул, тагын төчкерим дип, кояшка күзен кысып караган иде, ләкин бу юлы төчкерә алмады.* Һ.Такташ. *Су шактый салкын иде, ул, талпынып тегә як ярга чыгуга, бер-ике-өч тапкыр нык кына төчкерде.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Мотор, төрле механизмнар һ.б.ш.лар тигез эшләмәгәндә, өзек-

өзек тавыш чыгару. *Бернничә минуттан кызыл гаскәриләр төялгән йөк автомобиле, төчкерә-төчкерә, шәһәрнең борынгы үзгенә таба юл тота иде.* З.Фәтхетдинов. *Алар бәхетенә, юл авыш иде, урыннан бер купкач, машина үз җае белән балчык чәчә башлады. Бер төчкерде, ике, өч!* А.Гыйләҗев

3) *күч. эвф.* Табигый хаҗәтне үтәү. *Ишәккә түшәк җәйсәң, төчкереп төшәр.* Мәкаль

◊ **Төчкереп бирү** Мөһим дип санамау, әһәмият бирмәү. *Әнә бит, Мамадыштан Миләүшә Хәйруллина да: «Төчкереп бирәбез кризисына», – дип язган.* Татарстан яшьләре. **Төчкереп туганнар** *ирон.* Бик тере балалар. **Төчкереп тору** Куәтләү. *Геолог Нарский кеше әйткәнгә генә төчкереп торырга яратмый.* А.Әхмәт

**Төчкерә башлау** Төчкерергә тотыну. *Казанга җитәрәк Зөлфирәнең «мактаулы» машинасы тагын төчкерә башлады.* Г.Гыйльманов. *Трубканы куйгач, яңадан мониторга төбәлеп, клавиатураны эшкә җикте, һәм бернечә мизгелдән янәшә өстәлдә торган принтер кәгазь төчкерә башлады.* Х.Ширмән

**Төчкереп алу** Бераз төчкерү; бер тапкыр төчкерү. *Бер төчкереп алсаң, капка төбенә дә барып җитәсең...* Г.Әпсәләмов. *Сигез-ун малай хәтсез генә этеп баргач, мотоцикл чаф-поф килеп бер төчкереп алды да, кинәт кенә пытырдап, ук шикелле алга ыргылды.* А.Гыймадиев

**Төчкереп җибәрү** Кинәт төчкерү. *Җиһанша җизнинең борынына кояш нурлары кереп кытыкладьы, ул борынын күтәрде дә төчкереп җибәрде.* Һ.Такташ. *Нәкъ шул секундта класста кемдер төчкереп җибәрде, һәм «плантаге» шул тавышка күмелде.* М.Мәһдиев

**Төчкереп кую** Бер тапкыр төчкерү. *Бу юлы хуҗа алыптай авызын аз гына ерып елмайгандай итте дә алагаем бер төчкереп куйды.* С.Поварисов. *Куян яшеренгән җиреннән төчкереп куя.* Р.Фатихов

**Төчкереп тору** Даими, әледән-әле төчкерү

**ТӨЧКЕРҮ** II *и.* Төчкерек. *Гыйззәтуллин бу төчкерү аркасында әле үзенең нәрсәдән котылганлыгын белми иде.* М.Мәһдиев. *Чәйнәүне, йотуны, имүне регуляцияләү, шулай ук косу, төчкерү, йөткерү кебек саклагыч рефлекслар да минең шушы бүлекләре белән бәйле.* Биология

**ТӨЧЛЕГӘН** *и. бот.* 1) Агачның кабыгы һәм үзагачы арасындагы катлавында минераль һәм органик матдәләргә бай сыекча. *Яз көннәрендә тукраннарны каен суы, ягъни төчлегән эчәләр дип сөйлиләр. --- Төчлегән бик тәмле бит ул.* Г.Галиев

2) Агачның кабыгы астында яшь, яңа ясалып килә торган лайлалы узагач катлавы, яшь кайры; *русчасы:* **заболонь**

**ТӨЧЛЕГӘ́Н КОҢГЫЗЫ** *и. зоол.* Кабыгашарлар семьялыгыннан агач кайрысы һәм төчлегәне (*2 мәгъ.*) белән туклана торган вак корткыч; *русчасы:* **заболонник**. *Төчлегән коңгызлары күбәю*

**ТӨ́Ч-ТӨЧ** *ы. диал.* Бәрәч

**ТӨЧҮ** *ф.* 1) Төчеләнү (*1 мәгъ.*)

2) Күңел болгатырлык сасу, тынчу, сөрсү. *И төчегән, өшегән, Базда сакал үстергән.* Табышмак

3) Озак вакытлар төче ашамлык ашаганга, аннан күңел кайту, тозлырак ашамлык теләү. *Хәзер инде ул Гаҗиләә борыч бирсә дә еламый, шикәр салса да төчеми.* Ә.Гаффар

4) *күч.* Артык еш кабатланып күңелне кайтару

5) *күч.* Нәрсәдер тәэсирендә рухи һәм физик яктан йомшару, җебү. *Мин бераз төчегән булсам да, сер бирмәс өчен: «Кая, хатыннар, утырыгыз», – дидем.* Ә.Айдар

**Төчеп бетү** Бик нык төчү. *[Камил әфәнде] халыкка каршы инде бик төчеп беткән вәгазьләр укый.* Ф.Әмирхан. *Бер айдан артык бит инде [аларның] тозлы аш ашаганнары юк. Күңелләре төчеп бетте.* И.Гази

**ТӨШ** I *и.* 1) Йоклаганда күз алдына килә торган күренешләр, вакыйгалар, кешеләр һ.б.ш. *Бүген төнлә бер төш күрдем: ука сүттем йомгактан; Болай матур булмас иде, җан иңгәндер оҗмахтан.* М.Фәйзи. *Ул сагына улын һәм сине, Төшләреңдә күрә, йокласа ---.* Ф.Кәрим

2) *күч.* Чынга ашмаслык нәрсә. *Юк, юк, бу – төш, хыял, алданам!* Н.Исәнбәт. *Аһ, ник үрти мине хыял белән Тик тилертеп кайтмас язларым, Ник төш кенә минем шатлыкларым, Ник бетмәс өн – кайгы, газабым?!* М.Җәлил

◊ **Төшкә иңү** *к.* **төшкә керү**. *Ул инде минем төшемә дә иңә башлады.* Г.Кутуй. *Төшемә тикмәгә генә иңмәгәндер бит.* Г.Әпсәләмов. **Төшкә дә кермәслек** *к.* **төшкә дә кермәгән**. *Ахун хәзрәт урынына имам булып калу – бу инде төшеңә дә кермәслек бер бәхет!* Ә.Еники. *Хуш исле өр-яңа костюм. Төшеңә дә кермәслек.* М.Мәһдиев. *Гөлмәрфуга өчен үсмер чагында ук ләззәтле көннәр бүләк иткән егетнең хәзер каршында басып торуы төшкә кермәслек хәл иде.* З.Мәхмүди. **Төшкә (дә) кермәгән** Өмет ителгәннән күпкә артык, күз алдына да килмәгән. *Туйга илле сум, мәһәренә йөз илле сум булса, башкаларның төшләренә дә кермәгән ич әле ул.* М.Фәйзи; 2) Бик озак күрмәгән, очратмаган кеше яки нәрсә турында. **Төшкә (дә) кермәс** *к.* **төшкә (дә) кермәгән**. *Тәмленең дә тәмлесе. Деликатес! Дәүләт башлыкларының да төшенә кермәс.* Н.Әхмәдиев. **Төшкә кермәсен** Бик ямьсез, куркыныч нәрсә турында. **Төшкә керү** Берәр нәрсә, кеше төштә күрелү. *Күзләр килде, гөлләр шиңде... Инде төшкә керәсең... Төшкә кереп, искә төшеп Үзгемне өзәсең!* Х.Туфан. *Төннәремдә мине уятма син, Төшләремә кереп йөдәтмә.* К.Булатова. **Төш кебек (шикелле)** 1) Күптән үткән, күптәннән онытыла, чит була башлаган нәрсә, эш, вакыйга турында. *Ә җимерек арба калдыклары, кыйшык абзар-куралар, алты баганасы гына сураеп калган капка хәрабәсе хәзер монда чит, әллә кайчангы, сагышлы бер төш кенә кебек.* Ә.Гаффар; 2) Ачык булмаган. *Тик хәтерлим төшем кебек кенә Әтиемнең кайткан көннәрен, Каршыбызда басып, көлеп кенә, Кочагына алып сөйгәнен...* Ш.Маннур; 3) Бик кыска. *Ходаем, бу бит төш кебек кенә булып калды инде... Тагын кайчан күрермен инде мин сине?!* Г.Ибраһимов. *Әнә бит ул дөнья нинди, ә? Яшисең, яшисең... Ә гомер*

*күрелеп бетмәгән төш күк кенә икән...* Ә.Гаффар. **Төш кую** Истихарә кылу. **Төштә дә күрмәү** Нәрсәне яки кемне дә булса бик озак күрмәү, нәрсәгә дә булса ия була алмау; югалту. *Философ, булай булса, Кубрат хан кызын төшендә дә күрмәячәк.* М.Хәбибуллин. **Төштә (булган) кебек (шикелле)** *к.* **төштә күргән кебек (шикелле)**. *Төрле төстәге мәрмәр ташлар белән нәкышьләнгән бүлмәләрдә яшәү, йомшак түшәктә гамьсез рәвештә таң атканчы көн туганны көтеп яту – барысы да төштә булган хәлләр кебек кенә калды.* М.Хәбибуллин. --- *Нинди тәҗрибә алганын да төштә генә кебек хәтерли ул.* Т.Нәҗмиев. **Төштә күргән кебек (шикелле)** 1) Бик кыска вакытта яки бик күптән булгандай. *Галәветдин бабасы белән Гайшәбикә әбисен Миңнулла төштә күргән шикелле генә хәтерли.* В.Нуруллин; 2) *к.* **төш кебек** (*1 мәгъ.*). *Тик еллар үтә барган саен, ул көннәр ничектер чынлыкта булып үткән төсле түгел, ә бәлки төштә генә күргән кебек тоела башлады.* Ә.Еники. *Аның тешләрен мин төштә күргән кебек кенә хәтерлим, ә кулларын онытырга теләсәм дә оныта алмыйм, көчем җитми.* М.Юныс. *Краевка вокзалындагы ыгы-зыгы эчендә өзгәләнеп калган хатыннары, туганнары төштә күргән кебек кенә булып күз алдына киләләр, күңелләрен моңсуландыралар иде.* З.Зәйнуллин. **Төштә күрергә генә калу** Беркайчан да яңадан кабатланмаслык вакыйга, хәл турында. *Бу хәлләр җиргә барчасы бергә калган тик инде төштә күрергә.* Г.Тукай. *Урман буена чыгып, паласка кырын төшеп, озаклап-озаклап чәй эчүләр төштә күрергә генә калды.* Ф.Хөсни. **Төштә түгел, өндә** Чынлыкта. *Ышан йөрәк, инан бу кичәләр Төштә түгел өндә икәнгә...* Х.Туфан. *Тукта, Фазыл төштә түгел, өндә дәшә түгелме соң! Күзләрен уып, Мөнирҗан торып утырды.* Н.Әхмәдиев. *Бу бит төштә генә түгел, өндә дә үз-үзеңне ниндидер явыз каракошларга тотып бирү белән бер булачак!* Н.Фәттах

**ТӨШ** II *и.* **1.** 1) Көн уртасы, өйлә вакыты. *Эшендә төштән соң озак булмады Моназыйр ---.* М.Хуҗин. *Эчпошыргыч каникулның соңгы көннәрендә булса да туйганчы йоклыйм әле дип, төшкә кадәр урынымнан кузгалмадым.* А.Әхмәтгалиева

2) *астр.* Теге яки бу урынның меридианы аша Кояшның нәкъ уртасы үтү мизгеле // Көньяк юнәлеше. *Төш ягыннан җил исү*

3) *сөйл. к.* **төшкелек**. *Төшкә кайтыр алдыннан Мәһриҗамал, яңадан урган булып маташып, бармагын кисте.* М.Гали

**2.** *рәв. мәгъ.* Көн уртасында, өйлә вакытында. *Иртә уңмаган төш уңмас, төш уңмаган һич уңмас.* Мәкаль

◊ **Төш авышу (аву)** Көндезге уникe үтү. *Буяу, пумала, кыргыч, кадак, тагын әллә никадәр кирәк-ярак төяп, төш авышкач кына кайтып төште ул.* Р.Мулланурова. *Төш авышуга ук әйләнеп кайтты абыйсы.* В.Нуруллин. **Төштән соңга калган** Вакытыннан соң эшләнгән. *Менә шулай ул безнең мужик халкы [күп сөйли], ә иң кирәклесе һәрвакыт төштән соңга калган була.* Ф.Хөсни

**ТӨШ** III *и.* 1) Кайбер үсемлекләрнең җимешләрендә каты кабыклы орлык. *Мин ул хөрмәләрне ашар идем дә төшләреннән дисбе ясар идем.* М.Хәбибуллин. *Каты төшле җимеш юка тиречектән, сусыл йомшак өлештән һәм җимеш тирәлегенең эчке катламы булган каты төштән тора.* Биология. *Караҗимешнең төшләрен алып ваклап турарга [кирәк].* Серле календарь // Чикләвек һәм башка кайбер җимешләрнең каты катлавы эчендәге йомшак өлеше. *Сүз булсын өчен генә сөйләнә торган мәгънәсез һәм риялы сүзләр, төшләре алынып ташланган чикләвек кабыклары шикелле шалдыравыклы, ләкин кирәксез нәрсәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Яшәгез кайгы-шатлыкның Кадерен белеп кенә, Хәтта чикләвек төшен дә Урталай бүлеп кенә.* Ш.Галиев

2) *сөйл.* Тышча яки кузак эчендәге орлык. *Тегермән көне буе тик тора, эшләми, тартырга төш юк.* Р.Ишморат

3) *этн.* Майга салып пешерелә һәм балда катырыла торган йомры төймә формасындагы милли камыр азыгы; чәкчәк. *Өйгә күз төшереп алдым: утлар яна, ыгы-зыгы килеп хатын-кызлар чабулый, бизәкле чаршаулар эленгән, ястыклар, табында бавырсаклар, төшләр.* Ф.Хөсни. *Һәр өйдә, хәлле хәленә карап, кызарткан күкәйләр, ашап туйгысыз тәмле, кетердәвек төшләр пешерде.* Ш.Маннур. *Күчтәнәчкә ул [әни] төш пешерергә ярата иде.* М.Мәһдиев // Бавырсак. *Күреп ятам татлы төш: әнием пешерә төш.* Л.Шәех. – *Әй, төш пешерәм инде мин, коймак пешерәм. – Әби, әллә нигә гасабиланган йөзен киленгә таба борып, --- капкага таба юнәлде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

4) Берәр нәрсәнең уртасы, үзәк өлеше. *Күзгә күренмәслек утлы төшне Фейерверк итеп чөя белә. Шундый дәрәҗәгә җитте кеше: Теләсә, мең кояш күккә элә.* Ә.Баян

5) *физ.* Атомның тирәсендә электроннар урнашкан уңай корылмалы үзәге. *Без күк йөзендә ничә галактика, Җирдә күпме кош-корт, хайван, атом төшендә ничә нейтрон, ничә протон барын беләбез.* З.Мәхмүди. *Атомның төше тирәсендә чагыштырмача шактый зур ераклыкта электроннар әйләнеп йөриләр.* Физика курсы

6) *геол.* Җир шарының уртасында урнашкан, радиусы 3500 км чамасы булган һәм кремний белән тимердән тора дип фаразланган өлеше. *Җирнең төше ике катламга: эчке һәм тышкы төшләргә бүленә.* Табигать белеме. *Төшнең тышкы өлеше эрегән хәлдә, ә эчке өлеше каты булса кирәк.* Физик география

7) *биол.* Үсемлек һәм хайван күзәнәкләренең иң мөһим состав өлеше. *Цитоплазмада зур булмаган тыгыз тәнчек – төшчекле төш урнашкан.* Ботаника. *Инфузорияләрнең башка иң гади төзелешлеләрдән аермалы билгесе – күзәнәкләрендә төрле зурлыктагы, икедән ким булмаган төш булу.* Биология

8) *куч.* Берәр нәрсәнең иң мөһим өлеше, асылы. *Озын булса да, фикри төше ашалган чикләвек кабыгына охшаса да, без аларны «поэма» дип атадык.* Р.Батулла

◊ **Төшкә тарту** Ашлыкның төшен кибәгеннән аеру. **Төш кенә** Бик әйбәт, иң яхшысы, кыйммәтлесе, затлысы.

*Кечкенә дә төш кенә бу егет Габдулла Тукай иҗатына гашыйк.* Өмет

**ТӨШ** IV *и.* 1) Урын. *Ә минеке? Ә минеке ерак, Ерак әле моннан шулкадәр: Бу төшләргә килеп җитә алмый Ни бер сәлам, ни хат, ни хәбәр!* Х.Туфан. *Чаллыярның бу төшендә кайчандыр печәнле болыннар, кеше керә алмаслык әрәмәлекләр җәйрәп ята иде.* Г.Кашапов

2) *диал.* Берәр кешенең яки нәрсәнең тышкы кыяфәтендәге берәр билге, чалым. *Ул [сержант] аның [Мирхасның] кай төшендер танып бетерә алмый кебек иде.* Х.Камалов

**ТӨ́Ш БУЛУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә, урынга дучар булу, туры килү, тап булу. *Очтым гына, очтым, оч булдым, Очалмый торган төшкә төш булдым ---.* Җыр

2) Берәр урынга җайлану

**ТӨШЕМ** I *и.* 1) *сөйл.* Табыш, керем, килер. *Безнең өй авылның читендә, олы юлга салынган күпер башында булганга, бу базар көннәре минем өчен дә байтак төшем бирәләр.* Г.Ибраһимов. *Моның өчен хуҗа һәр «базарчы»дан ничә тиендер акча алып кала. Төшеме әйбәт булгандыр, ахры...* Ә.Еники

2) Иген сукканда: орлыкның чыгышы. *Әнә башланмаган биш йөз көлтә бар әле шунда, төшеме чибәр күренә, кырык поттан да ким булмас.* М.Гали

3) *күч.* Эшнең, хәлнең начарлануы. *Төштә – ат... Үлемгә, диләр, Төшемгә, диләр, Китемгә, диләр, Бетүгә, диләр.* Н.Арсланов

**ТӨШЕМ** II *и. лингв. иск.* Исемнәрнең башка җөмлә кисәкләренә бәйләнешен күрсәтә һәм төрләнү формаларында чагыла торган алты грамматик категориянең берсе; килеш. *[Г.Нугайбәктә] төшем алты төрдә була дип өйрәтелгән: атау төшем (баш килеш), тарту төшеме (иялек килеше).* В.Хангилдин

**ТӨШЕ́М ҖӨМЛӘ** *и. лингв. иск.* Тәмамлык җөмлә

**ТӨШЕ́М КИЛЕШЕ** *и. лингв.* Исемнең туры объектны белдереп, *кемне? нәрсәне?* сорауларына җавап булып килә торган килеше. *Кешеләр татарча килешләрнең урынын белми азаплана, ягъни төшем килешеннән соң кайсы килеш?* М.Мәһдиев. *--- ялгызлык исем белән белдерелгән туры тәмамлык, җөмләдәге урынына карамастан, һәрвакыт төшем килешендә була.* Татар грамматикасы

**ТӨШЕМЛЕ** *с.* 1) Файда, табыш китерә торган; керемле. *Аларга шул караҗиләк җыю төшемле генә кәсеп тә икән. --- Заготконторага тапшырсаң, савытына ун сум бирәләр.* С.Шәрипов. *Оренбург мәдрәсәсендә укуы өстенә бераз русча да белем алырга һәм шактый төшемле урынга кереп төпләнергә өлгергән Нәзир --- яучысын да, бүләген дә вакытында җибәрде.* Т.Әйди

2) Төшеме чагыштырмача зур булган, орлыгы күп чыга торган. *Төшемле көлтә*

**ТӨШЕМЛЕЛЕК** *и.* Төшемле булу. *Алыпсатарлыкның төшемлелегенә хәзер күпләр төшенде, базар урамы көннәнкөн озыная.* Ватаным Татарстан. *Күрәсең, каракларны әлеге эшнең төшемлелеге кызыктыра.* Татарстан яшьләре

**ТӨШЕМСЕЗ** *с.* 1) Керемсез, табыш китерми торган. *«Халык дошманы»ның хатынына колхозда иң төшемсез эшләрне генә, аларны да теләр-теләмәс кенә бирәләр.* С.Шәрипов. *Төшемсез колхоз эшендә эшләп, вакытсыз бөкресе чыккан яшьтиләрне күреп: «Акчаны киләчәктә дә болар шикелле вакланып тапмаячакмын», – дип күңелемдә беркеттем.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Файдасыз, кирәксез. *Ачуга ачу белән җавап кайтару – төшемсез, мәгънәсез эш.* Х.Камалов. *Бердәнбер җизнәсе, институт укытучысы белән бәхәскә кереп торуның төшемсез икәнен чамалап (ике кызы үсеп килә, укырга кертәсе була), тавыш кыйбласын үзгәртте ---.* Т.Галиуллин

**ТӨШЕ́М ТӘМАМЛЫГЫ** *и. лингв. иск.* Туры тәмамлык. *--- аның [төшем тәмамлыгының] төшем тәмамлыгы икәнен хәбәр белән ярашмавына, иядән соң килүенә, хәтта кайвакыт фигыльнең янында ук әйтелүенә карап беләбез.* Г.Алпаров

**ТӨШЕ́М ЮНӘЛЕШЕ** *и. лингв.* Теге яки бу эш-хәлнең объект тарафыннан үтәлүен, башкарылуын, кичерелүен белдерә һәм *-л, -ыл, -ел* кушымчалары ярдәмендә ясала торган фигыль юнәлеше. *Телдә төп юнәлеш белән мәгънәдәш яки мәгънәләре белән якын төшем юнәлеше формалары да күзәтелә: агу – агылу, туктау – тукталу, ыргу – ыргылу, ургу – ургылу һ.б.ш.* Татар грамматикасы

**ТӨШЕНДӘ** *бәйл.* Билгеле бер вакыт эчендә. *Соңгы атна-ун көн төшендә рәтле эш күрмичә һаман расходланып тору --- үзенекен иткән – кесә ягы шәп түгел иде.* Ф.Хөсни

**ТӨШЕНДЕРҮ** *ф.* Ачык, аңлаешлы итеп аңлатып бирү. *Яшь иҗатчыларны әдәби әсәрләрнең серләренә төшендерү булды аның төп максаты.* Х.Сарьян. *Шигырьләрне сүзен сүзгә тәрҗемә итеп, соңыннан Галина Измайловнага төшендерделәр.* Ф.Яруллин

**Төшендерә башлау** Төшендерергә тотыну

**Төшендереп бару** Эзлекле рәвештә һәрберсен төшендереп бетерү, һәммәсен, рәттән төшендерү. *Укучы һәм укытучыларның мондый нисбәте педагогикада өйрәнелә торган материалны укучыларга җиткерергә, аның үзләштерелүен тикшерергә һәм аңлашылмаган нәрсәләрне инде дәрес барышында ук төшендереп барырга мөмкинлек бирә.* Р.Һади. *– Билгеле, өстәмә рәвештә терминнарны рус телендә аңлатып, төшендереп барсаң начар түгел, – дип исәпли ул.* Ватаным Татарстан

**Төшендереп бетерү** Булган берсен төшендерү. *--- татарча гына төшендереп бетерә алмам дигәндәй, тагын да ныгытыбрак русча өсти торган иде.* Г.Әпсәләмов. *Мин, әлбәттә инде, өстәмә җылы кофталар, плащлар кигән хәлдә, яр буенда басып тора идем, төшендереп бирдем үзләренә.* К.Миңлебаев

**Төшендереп бирү** Төшенергә ярдәм итү. *Ә менә кеше булып калуның серләрен язып, сөйләп, аңлатып, төшенеп һәм төшендереп бетерергә мөмкинме?* Ф.Яхин. *Малай ике җөмлә белән генә нишләргә җыенганын төшендереп бирде.* М.Шаһимәрдәнов

**Төшендереп җиткерү** Тиешенчә бетерү. *Гөлсылуга өйләнергә ярамаганны малайга күрәзәче белән мин генә*

*төшендереп җиткерә алмаган идек, теге укытучы күршебез ярдәм итте.* Ф.Яруллин. *Икең дә сусаган, бер-береңне үлепләр тансыклаган мизгелләрдә ләззәтнең кадере бигрәкләр үзенчәлекле була бит ул, --- дөньяда яшәвеңнең мәгънәсе нидә икәненә тәмам төшендереп җиткерә.* К.Миңлебаев

**Төшендереп калу** Ниндидер форсаттан, мөмкинлектән файдаланып төшендерү; вакытында төшендерергә өлгерү. *Менә шул серләрне аның Наҗиягә нык кына төшендереп каласы килә иде.* Ә.Еники

**Төшендереп карау** Төшендерергә тырышу. *Башкаларга аның матурлыгын төшендереп кара инде, исен мактап кара!..* А.Гыйләҗев

**Төшендереп килү** Күптәннән бирле, даими рәвештә төшендерү. *Ләкин озак еллар буена аларны «ялган» саннар дип йөртәләр һәм «бирәчәк», «җитмәүчелек» итеп төшендереп киләләр.* Алгебра. *Моның шулай булуын безгә кечкенә чакта әти-әниләребез, мәктәптә укытучы апа-абыйларыбыз төшендереп килде.* Кайбыч таңнары

**Төшендереп тору** Һәрвакыт, даими төшендерү. *Укытучылар шулар күк Булса иде мөлаем... Яңа елда гел яңача Булыр иде фәннәр дә, Төшендереп торыр безне Илдәге уй-гамьнәргә.* Ш.Галиев. *Моны [хәбәрне] төшендереп торуның хаҗәте юклыгын да белә ул.* С.Поварисов

**Төшендереп үтү** Сүз уңаенда кыскача гына аңлату. *Кичәне редакция исеменнән иптәш М.Җәлил ачып, бу очрашудан күзәтелгән төп максатны кыскача төшендереп үтте.* Х.Туфан

**Төшендереп чыгу** Һәр кешегә аерым-аерым төшендерү

**ТӨШЕНЕКЛЕ** *с. диал.* Аңлаешлы, аңлашыла торган. *Башыннан алып ахырына кадәр тормышта булган вакыйгаларны күргәзгәнлектән, [әсәр] гаять гыйбрәтле дә, төшенекле дә.* Х.Кәрим

**ТӨШЕНКЕ** *с.* **1.** 1) Күпмедер дәрәҗәдә төшебрәк тора торган. --- *сугыш авырлыгының иң зурысын төшенке иңбашлы, чалара башлаган бу кеше үзе күтәргәнлектән, ул барында, бүтәннәргә җиңелрәк кебек сизелә иде.* Г.Бәширов. *Җиңе аның [күлмәкнең] шактый озын иде, һәм төшенке иде иңнәре.* Ф.Яруллин

2) Берәр башы яисә өлеше түбәнәеп, тәбәнәкләнеп торган. *Тигез басуның сул ягы буйлап таба кырые төсле түбән төшеп киткән ялпак тау киртләче сузылып бара. Шушы төшенке киртләч үрге әрәмәлеккә хәтле өзелми.* Ш.Камал

3) Тәбәнәк. *Тауның төшенке өлешен гөләп, сырганак куаклары басып киткән.* Йолдыз

4) *күч.* Боек, борчулы, пессимистик; кимсенүле. *Көннең берендә идарәмезгә Габдулла Карый килеп керде. Ябыккан, рухы төшенке бер хәлдә, авыруының начарлыгыннан зарлана.* Г.Исхакый. *Юлга аны төшенке күңел белән чыгарып җибәрмәскә кирәк.* С.Поварисов

5) *күч.* Боеклыкны, кимсенүне, пессимизмны чагылдыра торган. *Люциянең тавышыннан исә кәефе шушы кичтән дә төшенке икәне сизелеп тора.* М.Маликова. *Аның мондый төшенке кыяфәттә кайтуын Мостафа артык арганнан күрде, ял итсен, хәл алсын дип, борчымаска булды.* Ф.Сафин

6) *күч.* Өметсезлек, пессимистлык белән сугарылган. *Вак буржуа интеллигенциясенең 1905 елдан соңгы төшенке, ризасызлык настроениеләрен [С.Рәмиев] шигъри сурәтләрдә гәүдәләндереп чыккан.* Г.Нигъмәти. *Төшенке рухлылар фәлсәфәсе экзистенциализм дип, Аурупа фәйләсүфләрен өйрәнгән булдык.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Салынган, түбәнәйгән хәлдә

2) *күч.* Боек, борчулы кыяфәттә, боек, борчулы тавыш белән. *– Шулаймыни? – диде Әкълимә, төшенке генә.* Н.Фәттах. *– Барыгыз, – диде Тәнзилә, төшенке генә.* А.Гыйләҗев

**ТӨШЕНКЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Төшенке хәлгә килү

2) *күч.* Күңел төшү, кәеф кырылу. *– Ә хәзергә мин сезгә менә нәрсә әйтергә телим: мөмкин кадәр физик күнегүләр эшләргә, хәрәкәтләнергә кирәк. – Өзелгән нервларга хәрәкәтләнү генә нәрсә бирә соң? – диде Фәнияр төшенкеләнеп.* Ф.Яруллин. *Әмма кире чыгып китеп тә булмый, ул, кызга ишеттермәскә тырышып, тавышын әкренәйтеп, берничә сүз белән үзенең зарын әйтеп бирде, җөмләсенең ахырында тавышы төшенкеләнгәнен тойды ---.* М.Маликова

**Төшенкеләнә башлау** Төшенкеләнү билгеләре сизелү

**Төшенкеләнеп алу** Берара төшенкеләнү. *Күңел шулай уйчанланып, бер төшенкеләнеп алгач, ниндидер күтәрелеш тоя, тагы да күбрәк өметләр белән тула.* Х.Хисамов

**Төшенкеләнеп тору** Даими, һәрвакыт яки әле, хәзерге вакытта төшенкеләнү

**ТӨШЕНКЕЛЕК** *и.* 1) *сир.* Төшенке (*2, 3 мәгъ.*) булу, тәбәнәклек

2) *күч.* Боеклык; өметсезлек, пессимистлык. *Зөһрә ханым, сез дөрес күрәсез, әйе, миңа нидер булды, тик ул хәсрәт тә, төшенкелек тә түгел...* Ә.Еники. *Кичләрен --- хатын кинәт айнып киткәндәй була һәм, бу кешенең күңел төшенкелегенә мин гаепле бит, дип уйлап куйгалый иде.* М.Маликова

3) *күч.* Өметсезлек, пассивлык рухы. --- *Көн яктысын күрүдән мәхрүм калып, төшенкелеккә бирелгән кешеләр янына чакыргалыйлар шул кайчакта Бакыйны.* М.Маликова. *Зәнфирә башкалар кебек түгел: --- кайгырса, үзен юк итәр дәрәҗәдә төшенкелеккә бирелә.* Ф.Садриев

**ТӨШЕНКЕЛЕКЛЕ** *с.* 1) Үзендә төшенкелек чагылган. *Озын, ямансу һәм төшенкелекле тынлык.* А.Азимов. *Күңеле төшенкелекле булган кеше тиз картая.* Файдалы киңәшләр

2) *диал.* Аңлаешлы. *Минемчә, телнең әһәмияте «татарча яки төркичә» дип аталуында түгел, бәлки балаларга төшенкелекле булуында.* Х.Кәрим

**ТӨШЕНҮ** *ф.* 1) Кемнең, нәрсәнең яки нинди дә булса күренешнең, эшхәлнең асылын, барлыкка килү сәбәбен, мәгънәсен ачыклау. *Кызыннан болай гына котыла алмаячагын төшенгән Камил --- тирән-тирән сулыш алды ---.* Ф.Яруллин. *Фаяз, барысын берьюлы төшенгән хәлдә: – Беттем мин... Беттем... Харап иттем язмышымны, – дип пышылдады.* С.Шәмси

2) Берәр нәрсәнең, күренешнең һ.б.ш.ларның асылына акыл белән

ирешү, сәбәбен аңлау. *Кунаклар чыгып киткәч кенә, ул хатынының хәйләсенә төшенә.* Ф.Яруллин. *Тик аятьләрнең асылына төшенү нияте белән уйлана башласаң, сине Аллаһка ышанмауда гаепләргә ашыгалар ---.* Р.Сафин

3) Берәр нәрсәне белү, ачык итеп күз алдына китерү. *Бүген миңа мондагы ахирәт тормышы кебек тормыш бик кызык тәэсир итте. Мондагы эшләргә, серләргә төшенү авыр кебек тоелды.* М.Гафури. *Без китапның төзелеше, гомуми эчтәлек-тематикасы хакында аерым фикер-күзәтүләр белән генә уртаклаштык. Аны тулысынча белү, төшенү өчен, әлбәттә, басманың үзе белән шәхсән танышу зарур.* Х.Миңнегулов

4) Өйрәнү, уку һәм аңлашу процессында билгеле бер катлаулы нәрсәне аңлау. *Тик химиклар гына ул тозның серенә төшенеп, аның плюс ун градуста кристаллашып каты хәлгә килүен --- ачыкладылар.* А.Муранов

**Төшенә бару** Торган саен ныграк төшенү. *--- орыш һөнәренең нечкәлекләренә төшенә барган саен, Илбарысның күңелендәге хан кызына булган хисе дә ныгыды.* М.Хәбибуллин. *Әмма, әкренләп, [Нияз] татар кызлары Гөлйөзем, Мәрфуга, Зөләйха, Фатыймаларның Лидия, Людмила, Наташалардан һич ким булмавына төшенә бара.* Х.Миңнегулов

**Төшенә башлау** Төшенерлек дәрәҗәгә җитү. *Кешеләрнең тормышы һәм иҗаты турында язганнарны укыгач, күп нәрсәләргә төшенә башладым.* С.Шамов. *Тырыша торгач, Дамир теге агай сүзләренең мәгънәсенә төшенә башлады.* И.Хуҗин

**Төшенеп алу** Тиз арада аңлау, шунда ук төшенү. *Ләкин соңыннан төшенеп алды: юк, көлеп түгел, ә чын ихластан аны кадерләп, сөеп дәшү икән бу...* Ә.Еники. *Җәмилә җиңги хәлне бик тиз генә төшенеп алды.* М.Хәсәнов

**Төшенеп бетү** Тәмам төшенү, аңлау. *Хәзер мин мәдрәсәнең бөтен тәртипләренә, андагы хәлләргә төшенеп беткән идем инде.* М.Гафури. *Ничә ел утырып, шунысына төшенеп бетә алмады ул [Мөнирҗан]: --- тоткын әле килмәгән, кем киләсен төрмә начальствосы да юньләп белми, ә мондагылар бер ай, ай ярым алдан --- белеп, --- каршы алу хәстәрен күрәләр.* Н.Әхмәдиев

**Төшенеп җиткерү** *к.* **төшенеп бетү**. *Аңарда Фаяз төшенеп җиткермәгән сер бар сыман, һәм шушы сер егетне бәйләгән дә куйган.* С.Шәмси

**Төшенеп җитү** *к.* **төшенеп бетү**. *Чынында ул тәгин угланның үзеннән нәрсә соравын да төшенеп җитмәде.* Н.Фәттах. *Үзем дә төшенеп җитә алмаган хисләрне уяттыгыз сез, яшәү дәртен көчәйттегез.* Ә.Моталлапов. *Сөембикә, ул әйткәннәрнең бөтен мәгънәсенә төшенеп җитә алмаса да, аңа ачулы караш ташлап алгач, җәһәт адымнар белән чыгып китте...* Ф.Садриев

**ТӨШЕНЧӘ** *и.* 1) *лог.* Объектив чынбарлыкның һәм уйның, фикерләүнең аерым өлгеләре, кисәкләре, өлешләре турында конкретлаштырылган һәм гомум кабул ителгән фикер. *«Туган илем», «туган халкым» дигән иң мөкатдәс төшенчәләрне талисман итеп күңелләргә уйсаң да, ни кызганыч, күпмеләребез, --- вакытлы малга кызыгып, чит телләр диңгезендә батып кала.* М.Галиев. *Китапта татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы турында төшенчә бирелә ---.* Х.Курбатов

2) Күзаллау, караш, якын килү, аңлау рәвеше; билгеле бер нәрсә, күренешхәл турында кабул ителгән фикер, нәтиҗә. *Безнең авылда төшенчәләр башкачарак иде: фәлән җиңги бик тирләүчән дип, ипи басканда бик тирли дип, аның ипиен әҗәткә алмаска тырышалар иде.* Ф.Яруллин

**ТӨШЕРГЕЧ** *и.* Күчермә ясау (төшерү) өчен буяулы кәгазь. *Теге «мәлгуньнең» имзасы сырланган бер кәгазь табып кайтты да төшергеч аша минекенә күчереп куйды.* Т.Галиуллин

**ТӨШЕРЕЛМӘ** *с.* 1) Төшерелеп куела торган. *Төшерелмә күпер. Төшерелмә диван*

2) *лингв.* Ярымсузык иҗек ясагыч сузыктан соң килә торган. *Дифтонгоидларны татар теле галимнәре күтәрелмә һәм төшерелмә дигән төрләргә бүлеп йөртәләр.* Р.Абдуллина. *Мәсәлән, татар телендә төшерелмә -эй, -ий, -аэ дифтонглары кулланылмый.* Татар грамматикасы

**ТӨШЕРЕШ** *и.* 1) Төшерү рәвеше

2) Төшерү гамәле; төшерү очрагы. *Әйдәгез, патша төшереш уйныйбыз.* И.Гази

**ТӨШЕРҮ** *ф.* 1) Җанлы-җансыз нәрсәләрне югарыдан яки берәр нәрсә өстеннән түбәнгә таба күчерү. *[Тәбрия] такси машинасына кереп утырды, сулышы кысылганын сизеп, тәрәзә пыяласын төшерде.* М.Маликова. *Ирек медальонны үзенең башыннан чыгарды да Зәнфирәнең муенына төшерде.* Ф.Садриев

2) Транспорт чарасыннан чыгару, төшеп калырга мөмкинлек бирү, мәҗбүр итү, төшәргә кушу яки ярдәм итү. *Күрше авыл Чишмәледә шофёр төшереп калдырды.* М.Мәһдиев. *Автобус Акбуаны, аннан соң Иске Баулыны читтә калдырып узды да мине юл чатлыгында төшереп калдырды.* М.Юныс. *Бер стансада аларны вагоннан төшерделәр.* Г.Әдһәм

3) Нәрсәне дә булса түбәнрәк җиргә күчерү, илтү; кемне дә булса түбәнгә күчәргә күндерү, түбәнгә җибәрү, озату һ.б. *Кыз әнкәсе кызын төшерә су буена Киендереп, күркәмрәк күрендереп.* М.Фәйзи. *Кайвакыт абзыйлары Кыяметдиннәргә я бакчаларын казыша, я урманнан коры-сары утын төшерә ---.* А.Хәлим // Елга агымының юнәлеше буенча агызу. *[Әти] язгы ташкында, Урал тавы елгасыннан сал төшергәндә, батып үлде.* Г.Ибраһимов

4) Берәр нәрсәне кулдан ычкындыру. *Сөләйман хатны кулыннан идәнгә төшерә.* Һ.Такташ. *Шома егет тә аптырап калды, кәләшен кулыннан төшерде.* М.Маликова. – *Бу ут борчалары барып та кайтканнар икән,* – дип, *ул сеңлесен сак кына идәнгә төшерде.* Ф.Сафин

5) *гадәттә юкл. форм.* **төшермәү**. Өстендәге яки кулындагы әйберне салу, берәр җиргә кую, калдыру, ташлау. *Заһир абыйның: «Егет кеше үлгәндә дә коралны кулыннан төшерми!» – дигән сүзе истә иде шул, истә иде!* М.Маликова. *Өйгә кайтып җиткәнче, кызны кулыннан төшермәде ул.* Ф.Яруллин

6) Берәр нәрсәне салындыру, ию. *Мөхәмматов янә нәрсәдер әйтә башлаган иде дә, сүзе өзелеп калды, буйсынган кыяфәттә башын түбән төшерде.* Ф.Галиев. *[Вилдан] йөнтәс бүрегенең колакчыннарын төшергән, пальто якасын күтәргән.* М.Маликова // Берәр нәрсәне япканда яки каплаганда, аның күтәрелгән яисә өскә беркетелгән өлешен салындыру. *Аларны озатып өйгә кергән Гыйниятнең ишек келәсен төшергәне ишетелде.* Н.Әхмәдиев. *Бал суыртканда, ишекне бикләп куя, тәрәзәләрнең пәрдәсен төшерә.* И.Юзеев // Берәр нәрсәне үз урыныннан аска таба күчерү, салындыру, шудыру. *Сафиулла толыбын иңеннән төшерде дә, малайга җайлап япкач, үрәчәгә тотынып тышка сикерде һәм урыс чанасын куып китте.* Ә.Гаффар. *Укытучы, күзлеген борын өстенәрәк төшереп, журналга иелде.* А.Әхмәт

7) Яктылык яки күләгәне кая да булса юнәлтү. *Юан имән бүрәнәләрдән салган тегермән амбарлары гына, авыл өстенә кызыл шәүлә төшереп, төн буе янды.* М.Галәү. *Тирә-якта каплап алган, куе күләгә төшерә торган инҗир агачлары, алар астыннан саф сулы чишмә ага.* Ш.Әхмәдиев

8) Рәсемне яки бизәкне кәгазьгә һ.б.ш. нәрсәгә күчерү. *Почмакларына чәчәкләр төшерелгән шакмаклы дәфтәр бите аңа да утлы күмер булып тоелды ахрысы.* М.Маликова. *Чигү чигәм ак җирлеккә Ал җиләкләр төшереп.* А.Юнысова

9) *сөйл.* Берәр нәрсә язу. *Шуннан кәгазьгә төшерергә уңайсызрак сораулар китте, мин күзләремне йомып утырдым ---.* М.Мәһдиев. *Абзый, --- ручка алып, кызыл тышлы дәфтәргә зәңгәр кара белән Шаһбазның исем-фамилиясен төшерде...* Х.Ибраһим

10) Оригиналдагы берәр нәрсәне икенче бер нәрсәгә күчерү, аның рәсемен алу. *Япун журналисты --- ат караучы Фәйзрахмангаканыкты: – Фас! Анфас! – дип боерды ул аңа, әле алдан, әле арттан видеокамерасына төшереп.* Ә.Гаффар. *Бүген иртәнге якта телестудиядә безнең репетиция, ә төштән соң төшерәчәкләр ---.* Ф.Садриев

11) Берәр нәрсәнең билгеле бер өлешенә, кисәгенә туры китерү. *Татар димәктән, дикторларыбыз кайвакыт «татар» сүзен дә дөрес әйтеп бетермиләр: басымны беренче иҗеккә төшереп, «та́тар» диләр.* И.Низамов

12) Читтән килүчене кемдә дә булса кундыру, вакытлы рәвештә торырга кертү. *Башка кешеләр булса, мин аларны фатирга да төшермәгән булыр идем дә шул, солдат кешегә сүз әйтеп булмый.* Г.Камал. *[Кунакны] минем фатирга төшереп куй.* А.Гыйләҗев

13) Кемне дә булса килен итеп алу, үзендә кабул итү. *Мөнирҗан өчен Хәсьянов, бәлки, селкенмәс тә иде, Гайнияне килен иттереп төшерү өчен, ул үзенең Бурлы айгырын да кызганмады.* Н.Әхмәдиев. *Безнең якта туйларны кышын кыз йортында үткәрәләр дә җәйнең иң ямьле көннәрендә --- килен төшерәләр.* М.Кәрим

14) *иск.* Элекке мәдрәсәләрдә берәр яңа фәнне, дәресне үзләштерүгә күчерү, яңа китапны укыта башлау. *Дүшәмбе көнне --- килгән кыз балаларны кызы Сәгыйдә бисмилла әйтеп әлифбигә төшергәнне --- күреп, Хәйретдин хәзрәт тынычлап өенә кайтып китте.* Г.Исхакый. *Мине, башлап, «Иман шарты»на, иҗеккә төшерәләр.* Ш.Әхмәдиев

15) *сөйл.* Кая да булса илтү, җибәрү. *Ә әтисе: «Уттай эш өстендә автобусны эштән аера алмыйм. Көненә өч мәртәбә сыер савучыларны җәйләүгә төшерәсе бар», – дип кырт кисте.* Р.Вәлиев

16) *муз.* Күтәренке тонны салмаграк кына әкренәйтә бару, тонны түбәнәйтү. *Барган саен былбыл алга китә. Сайрый тавышларын арттырып. Бер күтәрә шунда, бер төшерә, Кай вакытта куя сызгырып.* М.Гафури. *Гади хикәя җөмләләре азакка таба тавышны төшерә барып, иркен сулыш алып туктала.* Г.Алпаров

17) Югарыдан түбәнгә таба сызу. *Өчпочмакның түбәсеннән каршы якка перпендикуляр төшерү*

18) Йөклелекне ясалма рәвештә өзү, вакытыннан алда тудыру. *Аның беркая читкә чыкмыйча, шунда – Яңа бистәнең ишегалды түренә поскан йортта бәбәй төшереп ятканын күршекүлән белмәмешкә салынды.* А.Гыйләҗев. --- *1936 елдан 1955 елга кадәр илебездә бала төшерүне тыйган канун үз көчендә иде.* Сөембикә

19) Агач кабыгын кәүсәсеннән аеру. *Әби коймак пешерә, Бабай кабык төшерә.* Такмак. *Абзыйлар шул озын һәм юан юкә агачларын бер дә кызганмый кисеп аударалар һәм, тагын да урталай кисеп, кабыкларын төшерәләр иде.* М.Гафури

20) Сүлпәнәйтү, киметү. *Вакыйгалар кызганда, этаждан этажга күчешләр тамашаны беркадәр суыта, спектакльнең темпын-ритмын төшерә.* Г.Арсланов

21) Ниндидер сәбәп аркасында яки ниндидер максат белән текстның, фильмның һ.б.ш.ларның аерым өлешен укымыйча, язмыйча кыскартып үтү. *Соңыннан алар [шигырьләр], бернинди төшереп калдырулар, өстәмәләр ясалмыйча, строфаларга салынып, шигырьләр булып чыга башлый.* Һ.Такташ. *Көндезге сеансларда фильмнарның үбешә торган урыннарын төшереп калдыралар.* К.Кәримов // Берәр документ составыннан кыскартып калдыру, исемлектән чыгару. *– Райкомның һәм райбашкарманың Яңа ел котлавында мактап телгә алынган хуҗалыклар арасыннан --- «Авангард» колхозы редактор тарафыннан махсус төшереп калдырыла. – Мин аны төшермәдем ---, – диде Ирек.* Ф.Садриев. *Мәкаләдә --- К.Мотыйгыйны Дәүләт думасына сайлауларда выборщиклар исемлегеннән төшереп калдыруга ирешүләре турында сүз бара.* Ф.Ибраһимова

22) Берәр эш, язу һ.б.ш.ны югары оешмадан, урыннан идарә иерархиясе буенча түбәнрәк торган оешмага тапшыру, җибәрү, юнәлтү һ.б. --- *икмәк җыярга дигән әмерне Мәскәүдән төшерделәр.* Р.Мөхәммәдиев. *Верховный Башкомандующий ставкасы зур елгаларны кичү турында директива төшергән иде.* Совет әдәбияты // Эштә куллану өчен, тиешле урынга тапшыру. *Яңа модельләрне производствога төшерү*

23) *күч.* Югалту, саклап кала алмау. *Фин, Ватан сугышлары үтеп, өч орден*

*алып, плен үтеп намусын төшермәгән егет иде ул.* З.Зәйнуллин

24) *куч.* Кемгә дә булса сугу. *Егетләр кияү егетен авыл башына таба алып киттеләр, авыл читенә чыккач, аңа бераз төшергәннәр ---.* М.Мәһдиев. *Канифә инде быел ук маңгай чәчен укытучысыныкы сыман кисеп тә караган иде, әнисе генә ошатмады: Канифәгә уклау белән берне төшерде.* Казан утлары

25) *куч.* Хакимияттән яки эш урыныннан мәҗбүри алу, идарә вазифасыннан азат итү. *Порттан чыгар өчен «экипаж үз урынында» дип расписка бирә белсәләр, мине капитанлыктан төшерәчәкләр.* М.Юныс. *1610 елны Василий Шуйскийны патшалыктан төшергәч, Мәскәүдә җиде боярдан хөкүмәт төзелгән.* М.Мәһдиев

26) *куч.* Берәр төрле рухи, эмоциональ, икътисади хәлдә калдыру. – *Шул, шул гына, эт җан, – дип, теш арасыннан сүзләрен кысып чыгарды кеше үтерүче. – Үзен дә җир астында кортлар кимереп бетергәндер, мине дә нинди көнгә төшерде...* Ф.Галиев. *[Шигырь-листовканың]* эчтәлеге: *ит-май-сөт-йон-бәрәңге-йомырка налоглары белән тоташ хәерчелеккә төшерделәр.* З.Зәйнуллин

27) *куч.* Берәр физик халәткә дучар итү. *Кыш көне куян куган малайлар белән җитәкчелек иткән Камчыбай, меңгән атын кара күбеккә төшереп, җәйләүгә чабып килеп керде.* З.Зәйнуллин

28) *куч.* Авыр хәлгә кую. *Көч хакимлек иткәнгә, бер милләт икенчесен коллыкка төшерә.* Д.Заһидуллина. *Михаил Венгриягә кача. Каменец шәһәрендә Ярослав аның гаиләсен әсир төшерә.* М.Гайнетдинов

29) *куч.* Кемдә дә булса билгеле бер хис яки фикер тудыру, кешеләр арасында билгеле бер мөнәсәбәт барлыкка китерү. *Шаһвәли аптырады, шулай да, шик төшермәс өчен, киенергә тотынды.* Г.Ибраһимов

30) *куч. сөйл.* Нинди дә булса эш өчен хезмәт хакы алу; акча эшләү. *Акчаны күп төшерә торгандыр, язган бер нәмәрсәсенә аерым түлиләр, ди, бит анда.* К.Тимбикова. *«Сантехприбор» ишегалдын, хуҗалык биналарын чүпчардан арулап, шактый акча төшергәннәр: Нәҗип җиде шешә сыра алып кергән.* А.Гыйләҗев

31) *куч. сөйл.* Юнәлеш килешендәге исемнәр белән килгәндә, шул исем белдергән күләмдә сарыф итү. *[Акчурин] моннан бер ел әүвәл, ун мең тәңкәгә төшереп, таштан бер мәктәп салдыр[ды].* Ш.Мөхәммәдев

32) *куч. сөйл.* Аракы, шәраб һ.б. эчү. *Мөниржан кичтән шактый гына төшергән иде.* Н.Әхмәдиев. *Минзакир – йортлар идарәсе слесаре – атна арасында өйгә бераз төшергәләп кайткаласа да, үзе бик юаш, сүз тыңлаучан кеше ---.* Р.Фәизов

33) *куч.* Какшату, зыян китерү. *«Минем хат алышкан кызым юк», – дип, дөресен әйтергә тиеш тапмады Бакый, дәрәҗәсен төшерәсе, сер бирәсе килмәде.* М.Маликова. *Аның азыптузып йөреп, йөз кызартачагы, болай да какшаган абруен бөтенләй төшереп китәчәге көн кебек ачык иде.* Ф.Садриев

34) *куч.* Берәр нәрсәне, эшне һ.б.ны билгеле бер якка, тарафка юнәлтү. *Икенче яктан, ул безнең имлямызны табигый вә фәнни юлга төшерә.* Г.Ибраһимов

35) *куч.* Нәрсәнеңдер мөһим күрсәткечен киметү, түбәнәйтү. *Кызның куллары ут кебек кайнар. Табиблар ничә көн инде аның температурасын төшерә алмый гаҗизләнәләр.* Х.Ширмән. *Шулай булмый ни, ил хуҗалары, үзара ярышып, әйберләрнең хакларын төшерә, берсеннән-берсе уздырып, пенсияләрне, хезмәт хакларын күтәрә...* М.Сәлим

36) *куч.* Өстенә йөкләнгән вазифаны, эшне бүтәннәргә күчерү. *Морат Мәрьямгә әллә ни өмет багламаса да, өстеннән бурычны төшерә.* М.Маликова

**Төшерә бару** Эзлекле рәвештә төшерү. *Ул --- үз күңелендә булган шигъри хисләрен кәгазьгә төшерә барды.* Ә.Исхак. *Фотохәбәрчебез кызыклырак мизгелләрне төшерә барды.* Ж.Дәрзаман

**Төшерә башлау** Төшерергә тотыну. *Кыз өстендәге киемнәрен әле аннан, әле моннан умырып төшерә башлады.* Ф.Яруллин. *Ул кичә бодай кыры эчендә чайкалган сыңар көнбагышны сурәткә төшерә башлаган иде ---.* Н.Гыйматдинова

**Төшерә бирү** Үз уңаена төшерүен дәвам итү. *Алар төшү белән шофёрлары машинасын кибет күләгәсенә куйды да, фуражкасын күзләренә төшерә биреп, күзләрен йомды.* З.Зәйнуллин. *Еламсыраган хатын дәвам итте: – Сине директорлыктан да төшерерләр инде шуның өчен. – Әйдә, төшерә бирсеннәр.* Р.Камал

**Төшерә төшү** Бераз төшерү; тагын да төшерү. *Бу көнне Россия Федерациясенең бөтен территориясендә Дәүләт флагларын төшерә төшәләр, сугыш елларында һәлак булганнарны искә алып, бер минут тын калалар.* Алга

**Төшерә язу** Чак кына төшерми калу. *Кәрам бу вакытта зажигалкасын чыгарып кабыза гына башлаган иде, Арсланов аны бәреп үк төшерә язды.* Ф.Садриев. *Тырыша торгач, үрелеп, машинаның ишегеннән ача торган тотканы борып өлгерде, ир-атны төртеп төшерә язды.* Х.Ширмән

**Төшереп алу** Тиз генә төшерү; аз гына төшерү. – *Менә бит... – Никитин тагын елмайды, – аннары әле, бәлки, кинога төшереп алырсыз...* Ф.Галиев. *Пляжда берәр ханым белән кызынып ятканын сиздерми генә рәсемгә төшереп алам да – менә сиңа компромат.* М.Маликова

**Төшереп бару** Һәрберсен, булган берсен төшерү. *Мин барлык гөнаһларымны тасмага төшереп бардым.* Ф.Яруллин. *Синхрон кинокамера ишетелгән импульсларны төшереп бара.* А.Муранов

**Төшереп бетерү** Барысын да төшерү; төшерүне тәмамлау. *Кәгазьгә төшереп бетерү белән, кыз сурәтен патша малаена күрсәтә.* Әкият. *Ә беркөнне, әсирләрне ерткычларча кыйнап, алардан канлы камыр ясаганнан соң, боларның барысын да җентекләп кинога төшереп бетергәч, җәзачылар арып ялга туктадылар.* Ф.Бәйрәмова

**Төшереп җибәрү** Кинәт төшерү. *Ул сумкасыннан банканы алып төшереп җибәрде, пыяла ватылган тавыш тонык кына ишетелде.* М.Маликова. *Бу коточыргыч хайванны күргәч, әби чырр*

*иттереп кычкырган да кәрҗиннәрен идәнгә төшереп җибәргән.* Р.Батулла

**Төшереп җиткерү** Тәмам аска кадәр төшерү. *Юл бик текә, Алла сакласын, мәтәлеп китүең дә бар. Ләкин машиналар таза кулларда, безне исән-имин күл читенә төшереп җиткерделәр.* Идел

**Төшереп карау** Нинди дә булса нәтиҗәне ачыклау өчен төшерү. *Иң элек бу минем үзем өчен уйлануларым, әдәби хезмәтемнең йомшак якларына билгеле бер анализ ясаган сыман, аны күз алдына китереп, шуларны кәгазь өстенә төшереп каравым.* Г.Бәширов. *Әллә чәй тәлинкәсен төшереп карарга-мы?* М.Хуҗин

**Төшереп кую** Төшкән хәлгә китерү; тиз арада яки алдан төшерү. *Пир ата аны уятырга да, уятмаска да белмичә, беравык урынында утырды да тышка чыкты, ишек чыптасын төшереп куйды.* Н.Фәттах. *Бүрекнең колакларын төшереп куйгач, күренми ул.* Ф.Яруллин

**Төшереп тору** Һәрвакыт, гел төшерү; әледән-әле төшерү. *Тик моңлы тавышы әле катырак, әле әкренрәк ишетелә, әйтерсең аны җепкә такканнар да бер күтәреп, бер төшереп торалар.* Г.Әпсәләмов. *Әлфреднең өй почмагы саен яшерен камералар һәр хәрәкәтеңне төшереп торадыр.* Ф.Яруллин

**Төшереп чыгу** Һәрберсенә, булган берсенә төшерү; баштан ахыргача төшерү. *Зур гына бөтен бер кәгазьгә, иренмичә, һәр буынның тармакланып дәвам итүен сызык һәм вак түгәрәкләр рәвешендә төшереп чыккан.* Ә.Еники. *Толь кисәкләренә төрле-төрле бизәкләр төшереп чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**ТӨШЕРҮЛЕ** *с.* Төшерелә торган; төшерелгән хәлдәге, төшерелмә. *Төшерүле күперчек*

**ТӨШКӘ** *бәйл.* Вакыт, чак. *Без кайткан төшкә штаб вагонында командирлардан берничә кеше --- җыелып утыра иде.* Ш.Усманов

**ТӨШКЕ** *с.* **1.** 1) Төш вакытындагы, көн уртасындагы. *Абыстай да, кызларның төшке сабакларын үткәреп, мулланы китергән ат белән ашка барып килә.* Г.Исхакый. *Кызлар, соңгы көннәрдә Сабира апаның үзләренә әллә ни игътибар итмәвеннән файдаланып, төшке ял вакытында олы бер көшел өстенә тезелешеп яттылар.* К.Тимбикова

2) Төш вакытында ашала, эчелә торган. *Икенче көнне без тауга менә алмадык: төшке аш вакытында очрашкач, Зөһрә ханым, башым авырта, кәефем юк, дип зарланып торды.* Ә.Еники. *Шундый көннәрнең берсендә сабан чәчүеннән төшке чәйгә кайткач, атымны башакка куштым да безнең ак өйдә яшәүче яшь мөгаллимә Хөршидә янына кердем.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ. к.* **төшке аш**. *Яңа бистәдә туган апалар бар бит минем, төшкегә шунда барам. Кайвакыт үзебез дә пешерәбез.* Ш.Хөсәенов

**ТӨШКЕ́ АШ** *и.* Көн уртасында ашала торган аш. *Яшелчә каравылчысы Хәбир бабай төшке ашка өйләренә кайтып киткән чакларда, башка малайлар кыярга кергәндә дә, алар өчен оялып, читкә йөгерә торган идем.* В.Нуруллин. *Менә төшке аштан соң роталар тезелешеп, җырлашып, казармаларга таралышты.* С.Шәрипов

**ТӨШКЕЛЕК** *и.* 1) *к.* **төшке аш**. *Мәктәпкә килгәндә, Кәрам төшкелек өчен ипи алып килми иде.* Ф.Яруллин. *[Кояш апагыз] Төшкелек ашар чак җитте дип, өйгә чакыра килгән.* Ә.Баян

2) Көн уртасындагы аш вакыты. *Мөнирҗан белән Фазыл, бер рейс ясап, төшкелеккә кайтканнар иде, урамнан табут күтәргән халык узып китте.* Н.Әхмәдиев. *Күп тә үтмәде, өй стеналарын селкетеп, капка төбенә Ислам машинасы килеп туктады. Егет төшкелеккә кайткан иде.* С.Шәмси

3) *к.* **төшлек** I (*1 мәгъ.*). *Мөнирҗан --- кояшның төшкелектән авышуын түземсезлек белән көтте.* Н.Әхмәдиев

**ТӨШКЕН** *с. иск. к.* **төшенке** (*1, 4, 5 мәгъ.*). *Бәйрәмсез көн — караңгы төн, күңел төшкен!.. Җитәр безгә, ямьсез-гафи көннәр бетсен!* Ш.Бабич. *Нишлим, дуслар, минем язмыш шулай, Төшкен күңелем Һаман моңлыдыр.* З.Бәшири

**ТӨШКЕНЛЕК** *и. иск. к.* **төшенкелек** (*2–3 мәгъ.*)

**ТӨШКЕ́ ЧӘЙ** *и. сир. к.* **төшке аш**. *Мостафин да, билгеле, бу көннәрдә төшке чәйгә һәм кичке ашка әбиләренә кайтып йөрде.* Ә.Еники. *Гел юк-бар белән маташып гаҗиз булган Нәҗип төшке чәйдән соң китәргә җыенды, «хатын, балалар көтә» диде.* А.Гыйләҗев

**ТӨШЛӘНҮ** I *ф.* 1) Төш белән өн арасында саташу; начар төш күреп саташу, бастырылу. *Улының төшләнгәнен ишетеп-күреп торган Рәхимә: – Улым, төшләндең ахры, борылып ят әле!* Х.Ибраһим. *Куркырлык берни дә юк икән. Бер саташу, утырган җирдән йокымсырап төшләнү генә булды, ахрысы, бу.* Р.Фәизов

2) *мед.* Йокы вакытында ирләрнең җенес орлыклары ихтыярсыздан бүленеп чыгуы; поллюция

**Төшләнә башлау** Төшләнергә тотыну. *Бик арыган Тукай үз номерында йокымсырап китә һәм шул чак төшләнә башлый ---.* Сәхнә

**Төшләнеп бетү** Төрле төшләр күреп, тәмам саташу. *Вакытлы-вакытсыз йокының ни хәере булсын. Төшләнеп, саташып бетте.* Н.Әхмәдиев. *Иван Васильевич --- начар ашый, начар йоклый. Черем итеп алганда да саташып, төшләнеп бетә.* М.Әмирханов

**Төшләнеп яту** Озак вакытлар дәвамында төрле төшләр күрү, төшләнү. *Әнә шулай төшләнеп яткан җиреннән уятып чакырып чыгаралар да әнине урлап алып кайтып китәләр.* Ватаным Татарстан

**ТӨШЛӘНҮ** II *ф.* Үзендә төш (III) барлыкка килү

**Төшләнә башлау** Төшләнүгә таба бару

**Төшләнеп бетү** Төш барлыкка килү процессы тәмамлану

**Төшләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә төшләнү

**Төшләнеп килү** Төш барлыкка килү процессында булу

**ТӨШЛЕ** I *с.* Төшләр күргән, төшләр булган. *Ул әле сәер төшле йокысыннан уянып җитмәгән, ул әле, һаман кулга-кул тотынышып, Сөмбел белән әкият сарае каршында басып тора кебек.* Р.Вәлиев. *Нигә шундый татлы иртәгез? Бүлмәс кебек төшле төнегезне Авып төшкәндә дә киртәгез.* Р.Рахман

**ТӨШЛЕ** II *с.* Төше (III) булган. *Мин, чикләвек буш булып чыга күрмәсен тагын дип, әчтән генә теләк теләдем. Шөкер, бусы да төшле иде.* Р.Зәйдулла

**ТӨШЛЕ** III *с. сир.* Урынлы

◊ **Төшле төшендә** Үз урынында, тиешле җирдә

**ТӨШЛЕК** I *и.* 1) Җир шарының теләсә кайсы урыны өчен кояш юлының күктәге иң югары ноктасы. *Инде төшлеккә менеп барган апрель кояшы класс эченә нәкъ шул яктан карый иде.* Х.Сарьян. *Төшлеккә җиткән кояш астында казык кебек туры торган гәүдәнең шәүләсез булуын малай белә белгән.* А.Хәлим

2) Төш вакыты, кояшның көндезге сәгать 12 дәге торышы. *Ул төн буе һәм икенче көннең төшлегенә кадәр эшләде.* Г.Кутуй

3) *диал. к.* **төшкелек** (*1 мәгъ.*). *Төшлектә дә юньләп ашамаган Нәҗмиевнең борынын кытыклап кергән тәмле исләрдән авызына сулар килде.* Ф.Садриев

4) *диал. к.* **төшкелек** (*2 мәгъ.*). *Бу урынга авыл көтүе төшлеккә туктый торган иде.* Ә.Гаффар. *Ислам да төшлеккә кайтмады, тамагын район үзәгендә яисә колхоз ашханәсендә туйдыргандыр инде.* С.Шәмси

5) *сөйл.* Көньяк. *Хәсән мулланың авылыннан өч чакрым ераклыкта, төшлек тарафында, төшлек тарафыннан төн тарафына ага торган су буенда, Искәндәр хаҗиның су тегермәнедер.* З.Һади. *Көн урталарында төшлектән рәхимсез эссе җил исәргә тотынды.* Г.Бәширов // Җылы климат зонасындагы җир. *Төшлеккә, җылы якка юнәлсәгез, Ихтимал, безнең илгә һәм җиткәйсез.* Н.Думави

6) *куч.* Берәр нәрсә үсешенең иң югары дәрәҗәсе, ноктасы. *Ай... ул гомер кабат кайтса, мин шул төшлегемә яңадан менсәм, нинди итеп яшәр идем!* Г.Ибраһимов

**ТӨШЛЕК** II *и. этн.* **1.** 1) Махсус ниятләп баш очына салып йоклагач, киләчәкне, берәр мәсьәләнең чишелешен, берәр кешене төштә күрергә мөмкин дип ышанула торган әйбер. *Мендәреңә төшлек куеп, төшкә кермәсме дип, йоклап киткәнсең.* Х.Камалов

2) Төш юрау китабы; тәгъбирнамә

**2.** *с. мәгъ.* Төш юрау белән шөгыльләнүче. *Төшлек карчык*

◊ **Төшлек салдыру** *этн.* Бер әҗер хисабына махсус «төш күрдереп» юрату, шул рәвешчә киләчәкне белергә тырышу. *Ялгыз калган хатын-кызлар, --- төшлек салдырып, фал китабы ачтырып, үзләренең иртәгәге көннәрен юрат[каннар].* Ф.Хөсни. *Ул, армиядәге улына төшлек салдырырга дип, күрше карчыкка гына кергән иде.* Х.Камалов. **Төшлек салу** *этн.* Нәрсәгә дә булса атап төш күрү өчен, баш астына кеше әйберен салу. *Ул көнне карчык безнең палатада янәшәмдәге ятакта баш очына төшлек салып йоклады.* Ватаным Татарстан

**ТӨШЛЕ́-ӨНЛЕ** *с. сир.* Йокылыуяулы. *Моны [Гайфулның] саташуы яки төшле-өнле йокысы дип уйларга мөмкин.* Ф.Хөсни

**ТӨ́Ш ӨСТЕ** *и. диал.* 1) Юка гына итеп җәелгән камырны майлап, киндер орлыгы сибеп, анннан катлы-катлы итеп төргәч шакмаклап кискәләп мичтә пешерелә торган камыр ашы; катлама

2) Ачы камырдан өстенә бәрәңге яки эремчек ягып пешерелә торган камыр ашы

**ТӨШ-ТӨЛЕК** *җый. и.* Һәртөрле төшләр

**ТӨШҮ** *ф.* **1.** 1) Югарыдан түбәнгә таба хәрәкәт итү. *Коля белән Петя шахтага төштеләр.* Н.Әхмәдиев. *Урусов аптырап беренче катка төште.* Ф.Садриев. *Ул кесә фонарен кабызды да, ватык кирпеч өеме аша сак кына үтеп, сайрак чокыр төбенә төште.* Ф.Галиев

2) Берәр җирнең үзеннән түбәнрәк торган ягына таба бару, китү, килү. *Әйдәгез, түбән урамга төшик әле, барысын да аңларсыз.* М.Мәһдиев. *Соң бит ул үзе дә, аны эзләп, авыл очына төшкән иде* ---. Р.Сибат

3) Берәр нәрсә өстендәге, югарыдагы урынын калдырып, җиргә, аска күчү. *Ул, манарадан төшеп, Самат ханның каршына килде ---.* Әкият. *Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә.* Ә.Еники

4) Транспорттан чыгу. *Трамвайларның ишекләре ачылды, ир-егетләр төште.* М.Маликова. *Заһидулла судан чыкты, Әхмәдулла көймәдән төште.* Р.Сибат

5) Су агымы уңаена хәрәкәт итү, берәр җиргә бару. *Кем бу? Нинди язмыш аны бу тирәләргә китереп ташлаган? --- Бәлки, ирек-азатлык өмет итеп, --- сал-бүрәнәгә ябышып елга буйлап йөзеп төшкәндер?* М.Хәсәнов. *Чынлап та, нәкъ аларга турылап, югарыдан тизйөрешле «Метеор» төшеп килә иде.* Р.Мөхәммәдиев

6) Өстән аска таба ыргылу. *Бер менеп, тагын уктай төшеп, Балык аулый җитез акчарлак.* Ш.Мөдәррис

7) Хәрәкәтен югарыдан түбәнгә юнәлтү. *Аяз көннәрдә кояш, --- Гатият тавы өстеннән тәгәрәп төшеп, --- бөтенләй юкка чыга.* Н.Әхмәдиев. *Кояш көнбатыштагы урман артына янтаеп төште.* Ә.Гаффар

8) Тигезлеген, тотрыклылыгын югалтып егылу, аву. *Ул бер селтәнү белән гәүдәсен өскә ыргытып, чалкан төшкән Сәеткә менеп атланды ---.* Ф.Латыйфи. *Алгарак ятып бар, ермаклар аркылы сикергәндә, ялга ныграк ябыш, төшеп калма.* М.Гали

9) Очып килеп үзеннән түбәнрәк булган берәр нәрсәгә куну; очып килеп җиргә утыру. *Безнең авыл янында гына --- күл бар. ---. Шунда ялга төшәләр иде киек казлар.* М.Хәсәнов. *Шулчак каракош очып төшә дә аның кулъяулыгын чукып алып китә.* Р.Сибат

10) Ыргытылган, атылган нәрсә очып килеп кайда да булса бәрелү; берәр урынга туры килү. *Ул арада немецлар --- граната томырдылар. Беренчесе читкәрәк төште.* М.Маликова

11) Нәрсә дә булса авырлыгы нәтиҗәсендә аска таба юнәлү. *[Яфрак] Һавага чөйгән вакытта [Гаязның] кесәсеннән пәкесе белән тарагы җиргә төште.* М.Әмир. *Әле үзе ялгыш җиргә төшкән алманы эләктереп, туп урынына авызына кабып уйнап та йөргән була.* Р.Сибат

12) Коелу, сибелү, чәчелү; түгелү. *Яхшы җиргә төшкән орлык гөл була.* Н.Исәнбәт // Җиргә коелу, яву. *Ул чак-*

*та хәзерге кебек көз ахыры иде. Кар төшмәгән әле төшүен, ә салкын җилләр исә.* Ф.Галиев. *Кинәт боз ява башлады. Салкын бөртекләр Гази атлый торган каткан җир өстенә төшәләр ---.* М.Хәсәнов. *Ел буена Ньясага ике мең миллиметрдан артык яңгыр суы төшә.* А.Муранов // Таму, агу. *Рәмилә --- үзе бала өстенә иелеп утырган, ике битеннән күз яшьләре агып төшкән.* Х.Камалов

13) Нәрсә дә булса үз урыныннан кубу, аерылып чыгу. *[Рашатның] --- уң яктан ике тешенең төшкәнлеге күренә.* Ф.Садриев. *Локман да: «Сәхия кызым, күлмәгеңнең төймәсе төшкән икән, кайту белән тагып куй», – дигән сүзләрдән акыллырак сүз таба алмады.* Ф.Яруллин. *Чиләкнең колагы төшү. Тырнак төшү*

14) Билгеле бер якка тәбәнәкләнү, түбәнәю, авышу; иңү. *Көнчыгыштан күл кырыена тикле, сөзәкләнеп, урманлы Кух сыртлары төшеп тора.* А.Муранов

15) Аска таба, түбән таба салыну; сәлперәю. *Бакчамдагы алсу гөлләр Сусыз төшкәннәр шиңеп.* М.Җәлил. *Газинең телефон трубкасын тоткан хәлсез кулы күкрәгенә шуып төште.* М.Хәсәнов

16) Үз урыныннан кубып аска таба күчү, аскарак шуышу. *[Малай] шуып төшәргә торган чалбарны ике кулы белән күтәреп тора.* Һ.Такташ. *Нинди биекләр алар: итәкләрендә торып, түбәләренә карасаң, башыңнан түбәтәең төшеп китәр.* Д.Аппакова

17) Нәрсәнеңдер сүтелеп, таралып, бер турыга кадәр салынып, асылынып торуы. *Дулкынланып иңбашына төшкән аксыл чәчләре --- белән ул әллә каян ук балкып күренә.* Ә.Еники. *Гөлүсә --- ара-тирә күкрәгенә төшкән авыр толымнарын артка чөеп ала.* М.Хәсәнов. *[Ваһапның] өстендә тезенә кадәр төшеп тора торган киндер күлмәк.* Ә.Фәйзи // Махсус көйләнгән каплавыч, япма, пәрдә аска таба шудырылу. *[Сәхнәдә] пәрдә тагын төште, тагын күтәрелде.* К.Нәҗми. *Арбаның брезенты салынып төшкән ягыннан Мансур Ибраһимовичның ботинкалары күренә.* Х.Ширмән

18) Дәвамлы рәвештә яки беркадәр вакыт кемнең яки нәрсәнең дә булса өстендә булу; өзеклек булу, кимеп тору. *Табыннан колбаса, сыр төшмәде, һәр кич итле ризык пешә торган булды.* М.Маликова. *Менә ничә көн инде иртәдән кичкә кадәр кулыннан төшмәгән балтасына карап куйды ул.* Р.Мөхәммәдиев

19) Ярамаган җиргә керү, ябырылу. *[Атны] ераграк куып җибәр инде. Игенгә төшә күрмәсен.* М.Фәйзи. *Гайниянең --- иң кадерле җимешенә корт төшүе беленәчәк бит.* Н.Әхмәдиев

20) Тулысынча каплап алу, биләп алу; иңү. *Урамга чыксам, тәмам караңгы төшкән.* Ә.Еники. *Туйганчы балык ашап, уха чөмереп утырганда, кичке салкын төште.* Р.Сибат

21) Берәр нәрсәнең өслегенә туры килү, турысына иңү, өлешчә каплау. *Абзар ярыгыннан кергән зәгыйфь яктылык печән өстендә таралып йоклап ятучы Зөһрәгә төшкән.* Ф.Яруллин. *Өстәлдәге эскизларга күләгә төшкәч, Морат башын күтәрде.* М.Маликова

22) Сыланучан яки сибелүчән матдәләр нинди дә булса өслеккә йогу, таралу. *Ул әле һаман пудыр ягынып бетерә алмый, пудыр ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята.* Г.Камал // Берәр өслеккә матурлык өчен ясалган, бизәлгән булу. *--- басу уртасында --- зәңгәр кыр чәчәкләре күргәч, Сәбиләнең зәңгәр бизәкләр төшкән яшел күлмәге чагылып киткәндәй булды.* Р.Вәлиев. *Ишек ачылуга, эре роза чәчәкләре төшкән халат кигән ап-ак чәчле Юлия Борисовна --- ярыктан карады.* М.Хәбибуллин // Нинди дә булса өслеккә ясалган берәр тәэсирдән барлыкка килү, хасил булу, ясалу. *Тамганы да бер сугуда салырга кирәк: тамга ачык, туры булып, бүрәнә башының өске кырыена, билгеле бер урынга төшсен.* Г.Әпсәләмов. *Кышлар җитсә, куян эзе төшә кырга, Ап-ак булып яр буенда тал бәсләнә.* З.Мансур

23) Фотоаппарат, видеокамера һ.б.ш.лар ярдәмендә ясалган язмада, кәгазьдә, плёнкада һ.б.ш.да кемнең яки нәрсәнең дә булса сурәте чагылу, эзе калу; шулар белән ясала торган язманың объекты булу. *Хөсәен [кинога] бик яхшы төшкән дип, күп сөйләделәр ул чакта.* Г.Әпсәләмов. *Икәү бергә төшкән фоторәсем дә җибәргән идем үзегезгә.* Р.Мөхәммәдиев

24) Берәр нәрсәнең өслеген каплау; берәр нәрсәнең өслегендә элпә сыман матдә хасил итү. *Төнге җил йоклагач, пар, тиз арып, такталарга бәс булып төшә.* Ә.Баян. *Таң белән, ач бүредәй, шыкраеп кырау төште.* Р.Сибат // Кеше тәнендә, үсемлек яфракларында һ.б. төрле өслекләрдә авыру билгеләре яки башка төрле үзгәрешләр барлыкка килү. *Бер елны да аның уңышы зарарланмады, кыярына шадра тап төшмәде, елдан-ел әмәлен кубәйтә барып, ул үз эшенең остасына әйләнде.* А.Гыйләҗев. *Нәркиснең битен язгы җил ашаган, борын очына асылташ тузаны кебек ике-өч бөртек вак сипкел төшкән.* М.Мәһдиев

25) Нинди дә булса авыру йогу. *Йөзләремнең нуры бетте, сары төште, Әҗәлнең вакытлары килеп җитте, ---.* Мөнәҗәт. *Кечкенәләрнең берсенә ютәл төшкән, икенчесенә – томау.* А.Гыйләҗев. *Җавап Руфинәгә ошады. – Кара син шаянны! – диде ул көләкөлә. – Әгәр томау төшсә?* Ф.Садриев

26) Кая да булса яшерен, рөхсәтсез керү. *Аннары язучы Габделбәрнең ертлач карунлыгы белән шулкадәр мавыгып китә ки, иң ахырда, инде җәзасын алгач та, аңардан бакчага төшкән малайны мылтыктан аттыра ---!* Х.Сарьян

27) Берәр җиргә сыеклык җыелу; үтеп керү. *Ана сөте һәрнәрсәгә шифалы шул. Нишләп Рәмиләгә һаман сөт төшми икән?* Х.Камалов. *Ул да түгел, бакчадагы бәрәңге базына язгы су төшкән булып чыкты.* Р.Мөхәммәдиев // Берәр әгъзаны кан басу. *Көне буена тук та тук килеп, кулбашларыңа кан төшә, уч төпләре беләүләнеп ката.* З.Хөснияр. *Еш кына тәнгә бетчәләр чыгу һәм күзгә кан төшү күзәтелә.* Сәламәт булыйк!

28) Нинди дә булса массадан билгеле бер нәрсә хасил булу, барлыкка килү; ясалу. *Шулай була бит ул: сөт өстен туглыйсың-туглыйсың, май төшми,*

*аннары, туглый торгач, болгаткыч белән ничектер бер китереп бәрсәң – сөт өсте куера да китә.* Х.Ширмән

29) Даими рәвештә эшли, үз функциясен үти башлау; барлыкка килү, ясалу. *Кар яуды, чана юлы төште.* М.Гафури. *Хәйдәргә хат язып салды: «Чыгарсалар, кая барыйм? Әллә Актанышка пароход юлы төшкәнне төрмәдә көтимме?»* Г.Әдһәмова // Билгеле бер транспорт чарасына юл ачылу. *Яз тәмам җитеп, пароходлар да төште.* Ф.Әмирхан. *Шулай көлә-көлә, ишеккә җиткәч, кире борылды да --- җырчы Сәхипкә килеп әйтте: – Син әзерлән. Арба төшү белән китәрбез. Минем атай бик чакырып яза.* Г.Ибраһимов

30) Билгеле бер сезонлы эшкә керешү, тотыну. *Бездә инде күптән уракка төштеләр.* Н.Фәттах. *[Колхоз идарәсендә] бухгалтер һәм кассирдан башка кеше юк иде, бүген печәнгә төшкәннәр икән.* М.Мәһдиев. *Ай-һай. Тырмага бер төшеп китсәк, тиз генә булыр микән ул иркен вакыт...* Н.Әхмәдиев // Берәр нәрсә эшләргә чыгу. *Прәнниге кибетнеке, Ипи үзебезнеке; Ничә төшеп биесәк тә, Тәпи үзебезнеке.* Җыр. *Китә күңел ачу, китә кара-каршы төшеп, ду китереп биешүләр.* М.Хәсәнов

31) *иск.* Элекке мәдрәсәдә берәр яңа дәресне, фәнне үзләштерергә керешү, яңа китапны укый башлау. *[Хәзрәт] кулыма бер китап биреп: «Мәнә бүген фарсы теленә төшәсең», – дип, шул китаптан сабак бирде.* М.Гафури. *[Хәйдәр], үзе дә сизмәстән, бөтенләй рус теленә төште.* Г.Ибраһимов

32) Кая да булса бару өчен җае чыгу. *Дамир каникулга кайтышлый Белоретта тукталгалады, Изолина да, Уфага юл төшкән саен, Дамирны күргәләде.* С.Шәрипов // Кемгәдер комачау итү яки, киресенчә, аның җаена тору; ярарга тырышу. *Шул ук көнне, сагалап торып, Гөлүсәнең юлына аркылы төшә бу ---.* Ф.Яруллин. *Генералга охшаган карт хәрби, як-ягында бер артына, бер алдына төшеп юргалап торган ике яшь офицер да бар.* М.Хәсәнов // Берәр нәрсә эченә, арасына керү, чуму, бату. *Мин, һичкемгә сиздермичә, төркемнән аерылдым да, ике бакча арасындагы тар сукмакка төшеп, өйгә кайтып киттем.* К.Миңлебаев

33) Хәрәкәт иткәндә төп юлыннан, кабул ителгән юнәлештән читкә чыгу, күчү, тайпылу. *Вагон рельстан төшкән, аны күтәрергә кирәк.* И.Гази. *Атының, каршы килүче йөкле ямщикларга юл бирү өчен, кырыйга төшеп батуы гына аның уйларын бүлдерде.* М.Гали

34) Берәр ниятка, фикергә, уйга килү. *1905 ел революциясеннән соң Г.Камал рәсми рәвештә газета чыгару фикеренә төшә.* М.Гали. *Һәр ике йорт, зур туй кылып, [кызны] кайнаталар йортына озату чараларын күрү уена төштеләр.* Г.Ибраһимов

35) Берәр нәрсә эшләргә теләк туу. *Сызылган таң яктысында күзләргә йокы төшсә дә, алар йомылмадылар.* А.Алиш

36) Кемгә яки нәрсәгә дә булса билгеле бер караштa булу; үз мөнәсәбәтеңне белдерү. *– Һәркемнең кайгысы да, шатлыгы да үзе белән, – дип, Нурисламның нииндидер киная салган сүзләренә каршы төште Ихтыяр.* Р.Вәлиев. *Мин «барма!» диярмен, ә син «юлыма абый гына аркылы төште» дип, гомерең буе миңа рәнҗерсең.* Ф.Садриев

37) Кемнең дә булса өлешенә туры килү. *Әгәр илгә таратсаң бер хәзинә, Бер акчадан төшәр һәр ай беренә.* Дәрдеменд. *Татар совет музыкасындагы куәтнең күп өлеше танылган композиторыбыз С.Сәйдәшев өстенә төшә.* М.Җәлил

38) Нәрсәнең дә булса аерым өлешенә гадәттәгедән күбрәк туры килү. *Күтәрелүче басым төшкән сузыкны аһәңлерәк яңгыратыр өчен, сузыбрак та укырга була ---.* Р.Абдуллина

39) Каян да булса килеп бер җиргә туктау, урнашу. *Әле көндез генә Әхмәтзариф абзыйларга өч кыз квартирага төшкән иде ---.* М.Мәһдиев. *[Изолина] әллә ни ахирәтлеге булмаса да, фатирга Рәйфәләргә төште ---.* С.Шәрипов. *Авылга кайткач, кемгә төшү, кайда тукталу хәл ителмәгән иде әле.* Р.Мөхәммәдиев // Кияү йортына күчеп килү. *Мин бит шушы йортка килен булып төштем.* Ә.Еники. *Нәрсә булган, ни булган? Мәш килә бөтен урам. Чистарта һәркем өен: Төшәчәк икән килен.* Ф.Яруллин // Кәләш йортына килү. *Шул арада бай хатыны Ярлыәхмәтне чакырып алып: – Бар, улым, урманга барып, утын алып кайт, – ди. – Иртәгә кияү төшәсе, мунча ягарга кирәк кияү килүгә, – ди.* Әкият

40) Вакытыннан алда туу, йөклелек өзелү. *Сөембикәнең баласы төшүен ул көнне Ирекстән ишергән булып чыкты врач.* Ф.Садриев. *Анда унтугыз көн дәваланып кайтса да, озак яши алмый әниләре, сигез айлык баласы төшү газаплары аны бу якты дөньядан мәңгегә алып китә.* Т.Нәҗмиев

41) Арзанаю, кимү, очсызлану. *Шәһәрдә --- товар бәясе төшә, дип сөйләгәннәр иде. Дөресме?* А.Шамов. *Шулай, франк төшә. Әйбер бәясе күтәрелә.* Г.Гали // *сир.* Берәр әйбернең бәясен, хакын киметү, арзанайту; бәяне чигерү. «*Аласызмы? – диде малай. – Алсагыз – азрак төшәм». Андрей көлеп җибәрде: «Бәясен әйтмәдең бит әле син, төшәргә*». Г.Минский

42) Нииндидер сәбәптән текстның аерым өлеше укылмый, язылмый, сөйләнелми калу. *Яздыгызмы? Хәзер карыйм. Бер хәрефе төшеп калган.* Г.Гобәй

43) Берәр исемлектән алыну, теркәлгән җирдән рәсми беркетелүне гамәлдән чыгару. *Инсия --- тору урынын алыштырды, пропискадан төште.* Ә.Моталлапов. *Аңлыйсы-нитәсе юк, мин инде пропискадан төшү турында да сөйләштем авылда.* Сөембикә

44) Берәр сулыкка кою, тоташу. *Агыйдел урманнар, таулар, калалар ашасыннан бара да Әчтерхан диңгезенә төшә.* Г.Ибраһимов. *Аннан агып яткан пычрак су Кондырча елгасына төшә.* Туган як

45) *күч.* Берәр нәрсә китереп бәрү, сугу. *Яңагына әнисенең кытыршы кулы килеп төшкәч, Миләүшә өнсез калды.* Ф.Яруллин. *Тукмактай йодрык төшүдән егет чайкалып китте һәм җиргә егылды.* Ә.Сафиуллин

46) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәтле булу. *Бу төче сүзләрнең иң зур өлеше соңгы вакытта Нәсимә адресына төшә.* К.Нәҗми

47) *күч.* Берәр ихтыяҗ туу, эш чыгу, кирәк булу. *Тартакиев --- өлкән инспек-*

*тор янына керде. Бусы – элекке таныш. Бер-берсенә эшләре төшкәне бар.* Х.Камалов. *Гидростройга барсагыз, борып җибәрмиләр инде. Үзләренең дә сезгә йомышлары төшә бит*... Р.Вәлиев

48) *күч.* Билгеле бер тарлыкка кереп эләгү; тотылу, кабу. *Атасы-анасы беләмикән? Балалары төшә тобага.* Җыр. *Бер персонаж урыс гаскәрләре камалышында калучыларны «капкынга төшкән бүре» белән тиңли.* Х.Миңнегулов

49) *күч.* Юнәлеш килешендәге исемнәрдән соң килеп, шул исем белдергән хәлгә дучар булуны аңлата. *Яралы атларны, мантымас хәлгә төшкәнче, өләшү дөрес, әлбәттә.* М.Хуҗин. *Морза, тархан Җидәннең буыны шушы мескенлеккә, бөлгенлеккә төшсен әле?!* Р.Сибат // Авыр хәлгә юлыгу; ниндидер бер кыен рухи халәткә дучар булу, юлыгу, тару. *Кияү җегетенең мондый хурлыкка төшүен күтәреп калу ярамый гуй, дип коткы салдылар.* Г.Ибраһимов. *Дөнья катлаулы, кеше башына әллә нинди хәлләр килә. Мин дә менә мондый хәлгә төшәрмен дип гомер уйламаган идем.* М.Маликова

50) *күч.* Идарә иерархиясендә югары органнардан түбәндәге оешмаларга җибәрелү, тапшырылу, бирелү (язу, директива һ.б.ш. тур.). – *Бүтән елларда яраган штат нигә быел гына кыскартыла? --- Берсе өскә төртеп күрсәтте, ягъни, аннан әмер төшкәч, без нишли алабыз?* Х.Камалов. *Югарыдан төшкән әмергә гомумән тел-теш тидерә торган гадәте юк иде аның.* Р.Мөхәммәдиев

51) *күч.* Дәвамлы эш-шөгыльнең объекты булудан туктау. *Өр-яңа өс-баш белән суга сикермәгән булса югыйсә, бүген чиста мунчага Мәсрурәсе белән аны җибәрергә тиеш булганнар. Күпме кирәк соң күздән төшү өчен!* Ф.Хөсни. *Чишмә һәр елны чистартылып тора. Авыл осталары аның өстен япкан, улаклар куеп бизәп җибәргән. Өченче чишмә игътибардан төшеп калган. Ул чистартылмый.* Ф.Гарипова // Берәр нәрсәнең, эшнең объекты булу; керү, эләгү. *Егет белән кыз тагын яман телгә төшәләр: әллә кем күргән имеш, Фатихә һәр көн кич, тәрәзә ачып, үзенең сөйгән егетен янына кертә имеш.* Г.Ибраһимов

52) *күч.* Берәр кешене яки нәрсәне үзенең объекты итеп алу. *Заһид Рәхмәтуллович ул күрсәткәннәрнең ачуын Ләлә ханымнан алды, алып бетермәгән өлеше үзенең кул астында эшләүчеләргә төште.* Ф.Садриев. *Әнием карт, өебез шәп, атым-сыерым, кәҗә-сарыгым бар, кенәгәдә байтак акча ята, умарта асрыйбыз – өйләнергә иде, ди. Гомумән, сиңа күзе төшкән.* С.Шәрипов

53) *күч.* Кемнең дә булса яман теләгенә дучар булу. *Әмма каһәр төшкән бу портрет, уйламаска тырышкан саен, күз алдына ешрак килде.* Ф.Яруллин. *Каргыш төшми калмый шул ул. Гомере буе кешегә яла якты.* Ә.Галиев. *Никадәрле кайгы-хәсрәтләр, чиксез югалтулар китерде безгә бу ләгънәт төшкән сугыш!* М.Хәсәнов // *теләк ф. форм.* **төшкере**. *Ләгънәт, рәхмәт, каһәр* һ.б.ш. сүзләр белән килеп, шатлану яки тиргәү, каргау кебек хисләрне белдерә. *Бар карап торганнары – абзардагы буаз сыер да өч баш сарык. Икесе бәрәнләде, өченчесе, рәхмәт төшкере мал, кысыр бугай ---.* Н.Әхмәдиев. *Надзиратель мине коридор буенча ишегалдына алып чыгып китте. Әллә инде камерага кайтара? Юк, ләгънәт төшкере, икенче якка борды.* И.Салахов

54) *күч.* Билгеле бер эшнең яки шөгыльнең кемнең дә булса вазифасына әйләнүе, аның бурычы булып саналу. *Югыйсә ишеткән иде: взвод саен берәр яшь солдат өлешенә төшә икән җыештыру.* С.Шәрипов. *Бу эш барысыннан да күбрәк кооперативта сакчы булып эшләүче Серый кушаматлы Сергей Храмм җилкәсенә төште.* Ә.Сафиуллин // Билгеле бер кеше өстенә йөкләтелү, салыну, билгеләнү, алыну. *Мулла абзый үзе түләсен, аңа төшкән налог ич ул!* А.Шамов. *Алпавыт урманында чикләвек ашап йөргән өчен, авылга штраф төшәчәк.* Ә.Фәйзи // Кемнең дә булса язмышына туры килү. *--- Гражданнар сугышыннан әйләнеп кайткач, Павел Иванович үзенең башына яңа зур хәсрәт төшкәнлеген белде: улы белән хатыны һәлак булганнар.* Г.Әпсәләмов. *Гадил айнып киткәндәй булган иде, чөнки башка берәүнең урынын алганын, башка берәүгә тиешле бәхетнең үз башына кинәт килеп төшкәнен аңлаган иде.* М.Маликова

55) *күч.* Акча, табыш килү, керем керү. *Шефның тырышлыгы аркасында үзенә яңа машина бирделәр, акчасы да яхшы төшә.* Ә.Сафиуллин. *«Чолман» безнең пароход белән бер линиядә, күмер, руда ташый. Эш авыр, акча төшми.* М.Юныс

56) *күч.* Билгеле күләмдәге акча, көч һ.б. бәрабәренә табылу. *Аннан да бигрәк, саман йорт бик арзанга төшә. Саман кирпече – дала шартларында мөмкин булган иң арзанлы төзү материалы.* Н.Фәттах. *Төптәнрәк уйлап карасаң, тавык ул сыер бәясенә төшә икән.* Ф.Яруллин

57) *күч. сөйл.* Нинди дә булса гамәлнең уңайлы моментка туры килүе, уңай булып чыгуы. *Язып маташуымны телгә алуы бик урынлы төште.* Ш.Камал. *Монда --- [гадилек] бар иде. Минем өчен бу ягы бигрәк шәп булып төште.* М.Гафури

58) *күч.* Нәрсәгә дә булса җай чыгу, форсат туу. *Бу разведка эше безнең өчен шәп кәсеп булып төште.* М.Гафури. *Бу – төтенле, буталчык халыклы бүлмәдән тизрәк таярга әйбәт сылтау булып төште.* Г.Ибраһимов

59) *күч.* Нәрсә дә булса әле генә әзер булу, дөньяга чыгу. *[Госман] хәзер табадан гына төшкән коймак алып кереп, ашъяулыкка куйды.* Г.Ибраһимов. *Машинкадан гына төшкән битләргә ни рецензент, ни редактор кулы тимәгән, каләм йөрмәгән.* Х.Сарьян

60) *күч.* Нәрсә дә булса элеккеге хәленә кайту. *Балалары, кайтып, мәктәпкә йөри башлады. Тормыш үз көенә төште.* Ф.Яруллин. *Ташу китеп, елга үз ярларына төшкән иде инде.* М.Хәбибуллин

61) *күч.* Нинди дә булса идарәчелектән һ.б.ш. эш урыныннан мәхрүм булу, азат ителү; китү. *Район кешеләрен көйләп-чөйләп тормасаң, тәртәгә тибү ягын гына карыйлар. Ә аның [Садрыйның] һич кенә дә «былач» башыннан төшәсе килми.* Н.Әхмәдиев.

*Кырык биш-илле яшьләрендә кеше хезмәттән төшеп калсын әле, кызганмассыңмыни аны?..* Э.Касыймов // Берәр эшкә, урынга сайланмау. *Кандидатларны --- сайлаганда, Садыйк мулла, --- Мөрсәлимов һәм тагы байтак кешеләр төшеп калды.* Г.Тукай. *Ул сайлауларны көтәргә булды: ихтимал, шул чакта җәнҗалсыз гына төшеп калырмын, дип өметләнеп торды.* Ә.Еники

62) *күч. юкл. форм.* **төшмәү**. Даимилек саклану. *Иргали абыйның --- исеме, макталып – телдән, сурәтләре гәҗит битләреннән төшмәде.* М.Хәсәнов. *Бабай намазлыктан төшми.* Р.Вәлиев

63) *күч.* Билгеле үзлекләрне чагылдырган күрсәткеч кимү, түбәнәю. *Кан басымының эше бер күтәрелеп, бер төшеп тору инде аның.* И.Нәбиуллина. *Ә күрсәткечләребез гел туксан тугыз проценттан түбән төшми.* Г.Тавлин

64) *күч.* Берәр нәрсәнең, күренешнең дәрәҗәсе, көче кимү. *Карчыкның бу тынычсызлыгы бер күтәрелде, бер төште.* Г.Ибраһимов // Абруй кимү, дан, дәрәҗә югалу. *Яхшы репутацияне яулавы бик авыр, ә бер төшә башласа, көч белән дә тотып кала алмассың ---.* Ә.Сафиуллин. *Кеше алдында дәрәҗәң төшү – иҗат кешесе өчен бик начар нәрсә...* М.Маликова

**2.** *ярд. ф.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер абстракт исемнәрдән соң килеп, шул исем белдергән халәткә бирелүне аңлата. *Егет кереп киткәч, Мәрьям куркуга төште.* М.Маликова. *Хәдичә, бернинди гаебе булмаса да, пошманлыкка төште ---.* М.Хәсәнов. *Бик борчуга төшкән ир, хәлне ниндидер бер яманга юрап, абзарлар тирәсен үзе әйләнергә булды.* Р.Сибат

2) Юнәлеш килешендәге кайбер абстракт исемнәрдән соң килеп, шул исем белдергән нәрсә белән каплану, шуңа бату. *Зиратның иң ерак читендәге яңа кабергә кадәр араны үтү безнең өчен тәмуг газабына тиң булды: без, тәмам арып, кара тиргә төштек.* Г.Тавлин. *Һич туктамый чапканлыктан, юлчыларның атлары да ак күбеккә төшкән.* Карчыга

3) Үзеннән алда килгән *-п* кушымчалы рәвеш фигыль белдергән хәрәкәтнең түбәнгә таба юнәлү мәгънәсен бирә. *Күрде Гази: ишелеп төшәргә торган шыксыз өй катында басып торган солдат янына әнисе йөгереп килде.* М.Хәсәнов. *Алар, бер ара узуга, Биектау үрен шуып төшеп, Заһидулла йортына таба җилдерделәр.* Р.Сибат. *Җиргә кара күләгә сикереп төште һәм эһ дигәнче кызны, бөтәрләп, икенче күләгәнең аяк астына ыргытты, арбага сикерде.* Ф.Латыйфи

4) Үзеннән алда килгән фигыль белдергән эш-шөгыль башкарылуына кинәтлек төсмере өсти. *Мин үз бүлмәмдә идем, ишектән кереп, безнекеләр белән исәнләшүенә тавышыннан танып алдым. Шундук әллә ничек коелдым да төштем, йөрәгем --- дөп-дөп тибә башлады.* Ә.Еники. *Голубевтан сорау алдык, безнең кулда какшамас дәлилләр барлыгын күреп, ул бик тиз җебеп төште ---.* Казан утлары

5) Үзеннән алда килгән *-а/-ә, -ый/-и* формасындагы фигыль белдергән дәвамлы эшкә интенсивлашу, көчәю, арту төсмере өсти. *Көннәр озыная төште.* М.Хәсәнов. *– Кем белә, – дип кенә куйды, сүз сөрешенең --- кучешенә аптырый төшеп...* Р.Сибат

6) Үзеннән алдагы фигыль белдергән эшнең өлешчә, аз гына башкарылуын яки башкарылырга тиешлеген күрсәтү өчен кулланыла. *Баш врач Газизга таба иелә төшеп, шактый кискен җавап кайтарды.* М.Хәсәнов. *Ул чагында инде юл азабы да кими төшәр иде.* Г.Минский. *Җил басыла төште.* Х.Ширмән

◊ **Төшеп калган буш шешә** *кимс.* Бернигә дә яраксыз, булдыксыз, булмаган, уңмаган. *Син, Шәңгәрәй абзый, юкны шыңгырап маташма! Синең белән без төшеп калган буш шешәләр инде!* Г.Ибраһимов. **Төшеп калган** *кимс. к.* **төшеп калган буш шешә**. *Аның бар өмете, бар хыял-максаты – бу хәлләрне, бу сынауларны гаделлек белән ерып чыгу иде. Ул бит төшеп калган мәми авыз --- түгел.* М.Хәсәнов. **Төшеп калганнардан түгел** Башкалардан ким түгел; булдыклы, шәп. *Үзенең бер дә төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килсә, кияү теләсә нинди сорауга оста, тапкыр җаваплар кайтарырга тиеш иде.* Н.Фәттах. **Төшеп калган әйбер** *к.* **төшеп калган нәрсә**. **Төшеп калган нәрсә** Бик арзанлы, буш, яраксыз, бернигә дә кирәксез нәрсә турында

**Төшә бару** Акрынлап төшү. *[Таңсылуның] әкрен генә кулы савылып төшә барды, төшә барды ---.* Х.Сарьян. *Караңгы төшә баруга да карамастан, аклык кимемәде.* Р.Мөхәммәдиев

**Төшә башлау** Төшәргә тотыну. *Бераз баруга юл түбән төшә башлады.* Ф.Яруллин. *Караңгы төшә башлады.* Җ.Дәрзаман

**Төшә бирү** Бернигә дә карамыйча төшүне дәвам итү. *Әнә бүреген кулына тоткан Отто да аэродромга таба йөгерә, ә очкыч һаман түбән төшә бирә.* А.Алиш. *Коралларын ташлаган кызыл сугышчылар --- башлары түбән салынган хәлдә калкулыктан түбәнгә таба төшә бирделәр.* Ф.Яхин

**Төшә тору** Бер-бер артлы һаман төшү; әлегә төшү; ниндидер эш башланмас борын алданрак төшә башлау. *Бөтен гәүдәсе белән агымга каршы торып күтәрелә, аннан чайкала-чайкала кирегә төшә торгач, Сылу суның салкынлыгына күнекте ---.* Р.Рахман. *--- җайдакларның кайсы яраланып, кайсы бөтенләй җансыз килеш җиргә егылып төшә торды.* Р.Сәгъди

**Төшә язу** Чак кына төшми калу

**Төшеп бару** Төшү процессында булу. *Болдырдан төшеп барган Күкәче меңбаш туктады, теләр-теләмәс кенә кире күтәрелде.* М.Хәбибуллин. *Ханым шарт итеп секундомерына басып өлгергәнче, Кадыйров инде баскычтан төшеп бара иде.* Ф.Яруллин

**Төшеп бетү** Тәмам төшү. *Ялгыз өйдә учак янында, теше төшеп беткән Убырлы карчык кыяфәтендә, Сихерче җеп эрләп утыра.* Н.Фәттах. *Кабыгы кибеп төшеп беткән чыршы утыны капка төбендә өелеп калды.* Ф.Галиев

**Төшеп җитү** *к.* **төшеп бетү**. *Сорыаксыл, тыгыз салкын күк өй түбәләренә үк төшеп җиткән, бөтен авыл чал кышка әзерләнеп тынып калган иде.* М.Мәһдиев. *Мәрьям йөргән тыярга тырышты, Шәукәтнең баскыч-*

*тан төшеп җиткәнен карап торырга сабырлыгы җитмәсен --- аңлап, --- автовокзалга таба китте.* М.Маликова

**Төшеп карау** Төшү мөмкинлеген сынау, төшәргә ниятләү. *Кыя бик текә иде, алай да Гомәр төшеп карарга уйлады, бәлки... Аның һич кенә дә дүрт чакрымны әйләнеп үтәсе килми иде.* Татарстан яшьләре

**Төшеп килү** *к.* **төшеп бару**. *Баскычтан шак-шок атлап төшеп килә иде.* Х.Камалов. *Ул да булмаган, Уктау сыртыннан, чәчләрен туздырып, теге бичура үзе дә төшеп килә икән.* Г.Якупова

**Төшеп китү** Кинәт, көтмәгәндә төшү. *Шунда каушавыннан Фазылның сәнәге кулыннан төшеп китте ---.* Н.Әхмәдиев. *Гайфулла, --- күз ачып йомган арада, --- ымсындыргыч сихри көч ташып торган гәүдәне күкрәгенә кысты. Зөһрәнең кияргә дип тоткан кофтасы кулыннан төшеп китте.* Ф.Яруллин

**Төшеп тору** Бертуктаусыз, еш, әледән-әле төшү; әле, хәзерге вакытта төшү; төшкән хәлдә булу. *Ул песи адымнары белән сукыр лампа яктысы төшеп торган кечкенә тәрәзәгә якынайды.* Н.Әхмәдиев. *Маңгаена батырып кигән түгәрәк бүрек читеннән колагына чал чәчләре төшеп тора.* Л.Ихсанова

**ТӨШЧЕК** *и.* 1) Кечкенә төш (III)

2) *биол.* Үсемлек һәм хайван күзәнәкләренең төшләрендәге (III) шарсыман кечкенә тәнчек; күзәнәк төше; *русчасы*: **ядрышко**. *Төштә еш кына 1–2 төшчек була.* Гомуми биология. *Цитоплазмада зур булмаган тыгыз тәнчек – төш урнашкан, төш эчендә төшчекне күрергә мөмкин.* Биология

**ТӨ́Ш ЧҮМЕЧЕ** *и. диал.* Тишекле чүмеч, сөзгеч

**ТӨЮ** I *ф.* 1) Төйгеч, тукмак, чүкеч кебек берәр каты нәрсә белән суккалый-суккалый, кат-кат бәреп ваклау, йомшарту, кабыгын төшерү, порошокка әйләндерү һ.б. *Ибрай һушын җуя язды. Йөрәге дөп-дөп типте. Аның урынында кемдер киледә кисап белән тары төямени!* М.Насыйбуллин. *Шул шул! Киледә су төергә яратабыз...* М.Хәсәнов

2) Берәр каты нәрсә белән баскалап тыгызлау; тыгызлап тутыру. *Алып кайткан азыкны әти-әни боларның авызларына төя-төя дә, шыррр дип кычкырып, яңадан китеп бара.* И.Гази. *Анда [чемоданда] елкылдап торган кеш тиреләре төеп тутырылган иде.* М.Юныс

3) *күч.* Бер урынга, бер төшкә еш-еш, кат-кат сугу, төйгечләү. *Уз-үземне белештерми, аның күкрәген төергә тотындым.* Ф.Яруллин. *Нурсөя мендәр төя-төя елады.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Кыйнау, тукмау. *Ә Урхан-Енисәй төркиләре аларны [кытайларны] күп тапкырлар төйгәннәр, акылга утырткалап торганнар.* Р.Сибат

5) *күч. гади с.* Күп итеп, туктамый ашау. *Безнең белән бер вагонда юл буе тавык итен төеп килгән кеше дә көрәшкә чыккан.* Ф.Хөсни. *Фәләх, сөмсезләнеп, бәрәңге төя.* А.Хәлим

6) *күч.* Кат-кат, кабат-кабат сөйләү, аңлату. *Әйтәсе сүзен, фикерен тыңлаучының миенә төя-төя тутыра.* Т.Миңнуллин

**Төеп алу** Тиз генә төю. *Хатыны арка үзәген дөп-дөп төеп алгач, ниһаять, ул кабымнарын йотып җибәрде.* А.Хәлим. *– Дөрес, яшьти! – дип, йодрыгы белән каты гына итеп өстәл төеп алды.* А.Әхмәтгалиева

**Төеп бетерү** Ахырга кадәр төю. *Нәфисә тарысын төеп бетергәч, аны җилпучка бушатып, җилгәрергә үк тотынды.* Йолдыз

**Төеп кую** Тиз арада төелгән хәлгә китерү; алдан төеп әзерләү. *Төеп куйган шомырт оннары, койган балан һәм миләш каклары аның келәтендә бервакытта да өзелмәде.* Ә.Фәйзи. *Мин Исламетдиннән берәр көянтә балчык сорап алып килермен, акбурны төеп куярмын, Нурия күп итеп су ташыр.* Г.Якупова

**Төеп ташлау** Тиз генә, тиз арада, аннан-моннан төю

**Төеп тору** Һәрвакыт, даими төю; әле, хәзерге вакытта төю. *Патша килгәндә, кыз киледә тары төеп тора икән.* Әкият. *Татарны талаган өчен, бер башкорт милләтчесен дә төрмәгә утыртмадылар бит, ә империянең шушы гаепләрен санаган өчен, татарларның гел башын төеп торалар.* Әдипләр

**Төя башлау** Төергә тотыну. *Миләүшә йодрыгы белән машинаның тәрәзәләрен төя башлады.* Ф.Яруллин. *Тегесе ачуы килгәндә генә бармак белән өстәл төя башлый иде.* Т.Миңнуллин

**Төя бирү** Бернигә дә карамыйча төюне дәвам итү

**Төя төшү** Бераз төю; тагын да ныграк төю. *– Төя төшәсең калган, монда әле бәрәңгенең кыстыбый тышын тишеп чыгарлык төерләре бар, – диде кайнанасы ачу белән.* Яңарыш

**ТӨЮ** II *ф. диал.* 1) Төенләү, төен итеп бәйләү. *[Гөлшаһидә] чем кара толымнарын биек итеп артка төеп куйган.* Г.Әпсәләмов

2) Йомарлау, төйнәү. *[Шәймәрдән] йодрыгын төя-төя, арты белән ишеккә юнәлде.* К.Нәҗми. *Хәзрәт вәгъдә иткән ун ел, әллә нинди җанлы сурәткә кереп, Галимҗанга йодрык төя, теш ыржайта, тел чыгарып күрсәтә кебек.* С.Поварисов

**Төеп кую** Төелгән хәлгә китерү. *Чем кара чәче шома итеп артка таралган, калын толымнары урап төеп куелган.* Г.Әпсәләмов. *Чемоданнан үзе теккән озын юбкасын тартып чыгарды, җиң очлары челтәрле кофта киде, баш артына тыгызлап төеп куйган сары чәчен сүтеп, тарап, иңнәренә салды, сөрмә тартты.* М.Маликова

**Төя бирү** Бернигә дә карамыйча төюне дәвам итү

**ТӨЯ** *и. диал.* Дөя. *Бүтән карчыклар изеп эчәргә төя тизәге бирәләр иде; миндә ул юк инде.* Г.Исхакый. *Борынтык агачына бәйләгән сүс бавы тартылып, борыны авырткан төяләр ямьсез тавыш белән акыргалап җибәрделәр.* М.Галәү

◊ **Төяне төге белән йотар** Комсыз, туемсыз

**ТӨЯГЕЧ** *и.* **1.** Йөкне күтәрә, төшерә, кыска арага күчерә торган җайланма, машина; *русчасы*: **погрузчик**. *Мөбәйнә төягеч чүмеченә беренче булып үзе бодай ыргытты.* М.Хөсәен. *Беренче суыклар башланганчы, кар төшкәнче дип, нефтьчеләр, бик авырлык белән генә, утрауга төягече, сәнәге, арбасы булган «Беларусь» тракторын китерделәр.* Я.Шәфыйков

**2.** *с. мәгъ.* Берәр нәрсә төяү өчен хезмәт итә торган, төяү өчен махсус

ясалган. *Иң алдан орлык төягеч машиналар үтте.* И.Салахов. *Хәзерге вакытта биредә бульдозер юлга түшәү өчен туфрак эттерә, төягеч трактор туфракны ике «КамАЗ» автомобиленә төяп тора.* Кайбыч таңнары

**ТӨЯГЕЧЛЕ** *с.* Үзендә махсус төягеч булган. *Төягечле баржа*

**ТӨЯК** *и.* 1) *иск.* Шәһәр, бистә. *Бетеп, вәйран булып, мәгъмүр төякләр. Җир астында тезелде ку сөякләр.* Дәрдемәнд. *Хәзер инде бөрҗәннәр төягендә, изге Бөрҗән уты храмы тирәсендә нинди чир купканын җентекләбрәк белергә дә мөмкинлек булды.* Б.Рафиков

2) *иск.* Аерым яшьтәге, җенестәге атлар өчен бүленгән көтүлек. *Айгыр әйләнер-әйләнер дә үз төяген табар.* Мәкаль // Гомумән, кемгә дә булса билгеләнгән җир, кишәрлек

3) *күч.* Туган җир, Ватан; күнегелгән тирәлек; сыеныр урын, торыр урын. *--- җан дуслар очрашуларны, бәйрәм табыннарын Басыйр Бариевичның туган төягенә – Идел буендагы авылга күчерделәр.* А.Гыйләҗев. *Вәлетдиннәрнең иңе-буе бер колач кына өйләре – безнең төп төягебез ул.* М.Кәрим

**ТӨЯЛҮ** ф. 1) *төш. юн. к.* **төяү**. *Эшелонга --- җыйнаграк кeләт чаклы ящиклар, машиналар, йөз төрле станоклар төялгән.* М.Хәсәнов. *Байкучатов белән Янбулатов туплар гына төялгән --- лафет өстенә утырдылар.* Т.Әйди. *Әйберләр машинага төялгән иде инде.* К.Тимбикова

2) Нинди дә булса транспортка күпләп утыру. *Алар өч машинага төялеп, урманга менеп киттеләр.* Ф.Яруллин. *Мөршидә апа безне оештырып бетергәч, ике машинага төялеп, шагыйрь авылына юл тоттык.* М.Мәһдиев

3) *диал. к.* **төяну** (*3 мәгъ.*). *Шуннан соң Салам-Торханнар тегеннән төялеп чыктылар кыз белән.* Әкият. *Хәсән бер кәрзин, бер чемодан һәм урын-җирләрен төреп салган төргәге белән бер «барабыз»га төялеп китте.* Ф.Әмирхан. *Мирза агай, әле сезнең торыр җирегез дә юктыр, әнә минем түрдәге зур өйгә бүген төялеп килегез ---.* Ф.Халиди

4) *күч.* Кемгәдер билгеле бер эш, шөгыль, кыенлык һ.б.ш. туры килү, төшү; ябырылу. *Утрауда булган бар яманлык, бар явызлык сезнең өскә төяләчәк хәзер.* М.Насыйбуллин

**Төялә башлау** Төялергә тотыну. *Ул да түгел, дусларым, артымнан күренеп, бераз читтәрәк торган өр-яңа «Жигули»гә төялә башладылар.* Ф.Яхин

**Төялеп бетү** Барысы да, берсе дә калмыйча төялү. *Башка олаулар төялеп бетмәгән иде әле.* Г.Әпсәләмов. *Бер чүмәлә печәнне чана өстенә ыргыту яшьтәшләр өчен уен гына иде. Сәгать тә үтмәде, йөк төялеп бетте.* Н.Әхмәдиев. *Бер сәгать дигәндә, машина төялеп бетте.* Ф.Садриев

**Төялеп тору** Әле, сөйләү моментында төялү; төялгән хәлдә тукталып тору

**Төялеп яту** *сөйл.* Төялү процессында булу. *Машиналарга капчык, сәнәк, балта, чалгы, пычкы күтәргән ирләр төялеп ята.* М.Мәһдиев

**ТӨЯНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **төяү**. *Иртәнге поезд белән Шәмси үзе корзиналар, чемоданнар, мендәрләр төянеп, Мустамаки станциясенә килеп төш[теләр].* Г.Исхакый

2) *к.* **төялү** (*2 мәгъ.*). *Бер извозчикка әйберләр төянеп, икенчесенә яшь хатын утырды.* Ш.Камал. *Без ашыгып-кабаланып төянергә тотындык.* Н.Фәттах

3) Берәр җиргә күченү максаты белән, барлык әйберләрне нәрсәгә дә булса төяп юлга чыгу. *Алар төянеп чыгып киткәндә, ярты авыл елады.* М.Мәһдиев. *Апалар төянеп Себердән кайтты әнә, бөтенләйгә, өч бала белән.* Н.Гыйматдинова

**Төянә башлау** Төянергә тотыну

**Төянеп бетү** Барысы да, берсе дә калмастан төяну

**Төянеп тору** Әле, сөйләү моментында төяну

**Төянеп яту** *сөйл. к.* **төянеп тору**

**ТӨЯ́Ү** *ф.* **1.** 1) Теге яки бу әйберне берәр транспорт чарасына салу, тутыру. *Нәкъ шундый көннәрнең берсендә мине сезнең авылга алма төяргә җибәрделәр.* Ф.Яруллин. *Ындыр табагында ашлык яна, дәүләткә икмәк төяргә кеше юк.* Ф.Садриев

2) Кешеләрне күпләп берәр транспортка утырту. *Ноябрь башларында безне, вагоннарга төяп, тагын көнбатышка таба алып киттеләр.* Г.Галиев. *– Кызлар, утырыгыз машинага, бәрәңге урынына сезне тупырдатып төяп алып кайтам! – дип чакырды.* Ш.Янбаев

3) Әйберләрне өсте-өстенә тутыру, күпләп урнаштыру. *Алмасыннан, әфлисуныннан, йөземеннән, вареньесыннан әллә никадәр нәрсә алганнан соң, кондитерга кереп, пирожныйлар, коры-сарылар төяде.* Г.Исхакый. *Чыгып китүләре дә ашык-пошык булды. Аш-су төяделәр дә чыгып тайдылар.* М.Насыйбуллин

4) *күч. гади с.* Күп итеп ашау. *Корсагыма чи бәрәңге төягән шикелле [булды].* Ф.Бурнаш

5) *күч.* Кемгәдер билгеле бер эш, шөгыль, кыенлык һ.б.ш. җибәрү, төшерү. *Язмыш барысын да бер кешегә төйи*

6) *күч.* Кемдер төрле эш, кыенлык һ.б.ш.ларны үзенә алу, күтәрү. *Борчудан авырайган иңбашларына яңаларын төяп, ул кичке сигезенче яртыларда гына кайтып керде.* Ф.Садриев. *Бар ачуымны эчемә төяп, мич башына менеп яттым.* Х.Камалов. *Авылдан болай кара гайбәт төяп чыгып китү килешми.* С.Поварисов

**Төйи башлау** Төяргә тотыну. *Теге дышлоларга әллә кемнәр әрле-бирле килеп ашыгып-ашыгып нәрсәләрдер төйи башладылар.* С.Җәлал. *Ташлытау кодагые кулындагы җәймәсен идәнгә салды да ду күчереп шкафтан савытсабаны төйи башлады.* М.Мәһдиев

**Төйи төшү** Тагын да күбрәк төяү

**Төяп алу** Тиз генә төяү. *– Тәк, болай итәбез, – дип, сәгатенә күз төшереп алды Юра, – ун минуттан синең янга «Газель» килеп туктар, төяп алырлар егетләр.* К.Кара

**Төяп бетерү** Ахырына кадәр төяү. *[Саламны] төяп бетерәм дигәндә генә, --- җил кузгалды.* Н.Әхмәдиев. *Миңа: «Кораб иң күбе бер тәүлек тора алыр. Без аны дүрт-биш сәгатьтә төяп бетербез», – диделәр.* М.Юныс

**Төяп карау** Нәрсәнең дә булса сыйдырышлылыгын сынау өчен төяү. *Төяп карасаң, бер олауга гына сыеп та бетмәс иде бу кадәр уй.* Г.Рәхим

**Төяп кую** Алдан төялгән хәлгә китерү; тиз арада төяү. *Атларны ял иттерәсе, йөкләрне төяп куясы бар.* С.Зыя-

лы. *Егетләрнең кәефле вакытларыннан файда күреп калырга ашыга: – Ягез әле, хуҗабыз килеп җиткәнче, менә бу мебельне машинага төяп куйыйк әле, алтыннарым!* Т.Галиуллин

**Төяп тору** Әле, сөйләү моментында төяү; даими, һәрвакыт төяү. *Бабайлар балчыкны носилкага төяп тора, без аны өскә ташыйбыз.* Идел

**Төяп яту** *сөйл.* Төяү процессында булырга. *Әхәт абый белән аның иптәшләре, андагы кечерәк кенә агач өйне сүтеп, арбаларга төяп яталар.* Л.Гыйззәтуллина

**ТӨЯҮЛЕ** *с.* 1) Нәрсәдер төяп куелган; тулы. *Тикшерүче комиссия монда килеп җиткәч, складка тапшырылган әзер продукцияне кәгазьләр буенча гына барлап чыкты да озатылырга әзерләнгән төяүле арбаларны да күреп канәгать калды.* Д.Бүләков

2) Төялеп беткән, төялгән. *Шахтадан күмер төяүле икешәр яисә дүртәр вагонетка күтәрелә.* Ш.Камал

**ТПРУ** *ы. к.* **трр**. *«На!» – дисәң, бармый, «Тпру!» – дисәң, туктамый, Печән салсаң, ашамый.* Табышмак. *Имеш, куучылар, артыннан җитеп, атына «тпру» дип дәшеп караганнар, ат аның саен элдереп чаба икән.* М.Мәһдиев. *Фәйрүзә апа тигез тешләрен күрсәтеп ягымлы гына елмаеп куйды һәм: – Тпру! Кил әле монда, – дип, атын туктатты ---.* В.Нуруллин

**ТРА́ВЕРЗ** *и. лат. диңгез., авиа.* Корабль яки самолёт алган курска карата перпендикуляр юнәлеш. *Сул траверзта утрау күренү. Траверзка чыгу*

**ТРА́ВЕРС** *и. лат.* 1) *хәрби* Флангтан яки тылдан ачылган дошман утыннан саклану өчен, окоп яки ныгытма кырыйларына өелгән ком, балчык, таш

2) *тех.* Ярдан елганың уртасына таба сузылган кечерәк дамба

3) *спорт* Берничә түбәне тоташтырган тау тезмәсе сыртлары буйлап салынган маршрут. *Ярыш шартлары буенча, алар берничә этапны үтәргә тиеш булдылар: колга буйлап йөрү, --- багана буенча узу, траверс, текә урыннан төшү һәм башкалар.* Татарстан яшьләре

**ТРА́ВМА** *и. гр.* 1) Яралану, пешү, бәрелү кебек тышкы тәэсир нәтиҗәсендә тән тукымасы яки әгъзалар имгәнү, җәрәхәтләнү. *Самолётын фашистлар бәреп төшергәч, парашюттан сикереп, җиңелчә травма ала Прищепа.* Р.Мөхәммәдиев. *96 килограммлы егет шулай ук пейнтбол, футбол уйнарга да ярата, ә көрәшне травма алу куркынычы булган спорт төре дип саный.* Тамаша

2) Берәр тетрәндергеч сәбәп аркасында психикага китерелгән зыян; күңел ярасы. *[Хатынның] авыруы, һичшиксез, ниндидер рухи травмадан соң башланган.* Г.Әпсәләмов. *Алар арасында тумыштан авыру булып туучылар да, ниндидер психик травма кичерүчеләр дә бар.* Татарстан яшьләре

**ТРАВМАТИЗМ** *и. рус* Нинди дә булса мохит, эшчәнлек белән бәйләнгән һәм шуларга хас травма алу очраклары, аларның ешлыгы. *Юллардагы травматизм хәттин ашканга күрә, Мәскәү – Уфа юлы кебек зур трассаларда махсус медицина үзәкләре оештырылачак.* Ватаным Татарстан

**ТРАВМА́ТИК** *с.* 1) Травма белән бәйле, травма нәтиҗәсендә булган. *Күптөрле баш ялалары һәм сул бот сөяге сынуы аркасында, травматик шок халәтендә ул Яшел Үзән район үзәк хастаханәсенә җибәрелә.* Кәеф ничек?

2) Травма ясый торган, травма китереп чыгара торган. *Травматик корал алырга теләүчеләрнең 90 проценты – 25 яшь тә тулмаган егет-кызлар.* Ватаным Татарстан. *Моңа кадәр рөхсәт ителгән травматик һәм газ пистолетлары белән шаяручылар да көннән-көн арта.* Татарстан яшьләре

**ТРАВМАТО́ЛОГ** *и. гр.* Травматология белгече, табиб. --- *чираттагы пациент килеп кергәч, травматолог Гайсин урыныннан кузгалып куйды.* Ф.Баттал. *Тагын бер травматолог бар, анысы ярты сәгать элек кенә машина авариясендә нык зыян күргән берәүгә катлаулы операция ясый башлаган.* Н.Әхмәдиев

**ТРАВМАТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның травмаларны һәм аларны дәвалау юлларын, ысулларын өйрәнә торган тармагы. *Медицина институтының травматология бүлегенә салдылар.* З.Зәйнуллин. *Горький урамына урнашкан травматология һәм ортопедия институтында танышы эшли иде.* Ф.Яруллин

**ТРАГЕ́ДИЯ** *и. гр.* 1) Драма әсәренең кискен бәрелешләр, сурәтләнгән геройларның һәлакәте белән тәмамлана торган төре. *Драманың һәркайсы жанры – трагедия дә, комедия дә, драма да – безгә хезмәт итәргә тиеш.* М.Җәлил. *Т.Миңнуллинның татар халкы тарихында зур урын алып торган тарихи шәхесләргә багышланган драма һәм трагедияләре: «Канкай улы Бәхтияр», «Без китәбез, сез каласыз», «Моңлы бер җыр».* Татар әдәбияты

2) Зур бәхетсезлек, фаҗига. – *Бәлки, берәрсе мәхәббәт трагедиясе белән палубадан Волгага сикереп төшәр әле, – дип, югары карый башладым.* Һ.Такташ. *Тормышта комедия белән трагедия, ягъни көлкеле хәлләр белән фаҗига гел янәшә йөри.* Н.Хәсәнов

**ТРАГЕ́ДИЯЛЕ** *с.* 1) Фаҗигале, трагик. *Ул иплән бәйләде дә, ярым көлкегә салып, үзенең трагедияле вакыйгасын сөйләргә керешге ---.* Г.Ибраһимов. *Мин бөек режиссёр Станиславский! Хәзер үзегезгә бөек, музыкалы, трагедияле, драмалы комедия куям!* Г.Каюмов

2) Тирән рухи газап, фаҗига белдергән. *[Шаһ] әллә нинди эчке рәнҗүле, трагедияле тавыш белән ялынып әйтте.* Г.Ибраһимов

**ТРАГИЗМ** *и. рус* 1) Драма яки музыка әсәрендә һәм аларның башкарылуында трагик элемент. *Эчтәлек һәм гомуми эмоциональ яңгыраш ягыннан шуңа якын «Таһир – Зөһрә», «Ләйлә илә Мәҗнүн» --- һ.б. шундый дастаннарның барысы да тирән трагизм белән сугарылган.* Ф.Урманчеев. *Ачы сарказм һәм трагизм белән комизмның янәшәлегенә нигезләнгән гротеск пьесаның төп нигезен тәшкил итә.* Р.Фәтхрахманов

2) Берәр нәрсәнең фаҗигале, күңелсез ягы. *[Дәрдемәнд] поэзиясендә трагизм һәм өметсезлек настроениеләре [сизелә].* Г.Халит. *Трагизм бүгенге көндә болай да күп...* Л.Фәтхетдинова

**ТРА́ГИК** I *с.* 1) Трагедиягә (*1 мәгъ.*) бәйләнешле. *Бер очрашуда, Айрат абый, Сез гасыр башында яшәгән трагик актёр Мохтар Мутинның гаҗәеп*

*оста шигырь укучы, шигырь сөйләүче булганын әйткән идегез...* Р.Вәлиев. *Тарихи җырларда чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт күбрәк трагик, драматик һәм героик планда чагылыш таба.* М.Бакиров

2) *сәнг.* Трагедиянең асылын тәшкил итә торган; килешмәүчән конфликтны, капма-каршы якларның кискен көрәшен чагылдыра торган. *Бу әсәрдә дә трагик [бәрелеш] элементларның булуы мәҗбүри.* Казан утлары. *Трагик мөнәсәбәтләрнең төгәл эшләнеше белән көчле тәэсир ясаган бу әсәрдә артистлар Зөлфирә Зарипова, Нариман Гарифуллин, Әзһәр Шакиров, Шамил Бариевның иҗади мөмкинлекләре яңа яктан ачылды.* Сәхнә

3) Трагедия геройлары рольләрен уйнаучыга, башкаручыга хас; трагедия уйнау белән бәйле. *Трагик талант*

4) Фаҗигале халәтне белдерә торган. *Әллә нинди трагик тавышлар белән --- сөйләнеп, минем арттан үзе килде.* Ш.Маннур. *Караңгы декорацияләр, сәләмә киемнәр, авыр трагик музыка, күк йөзен каплаган кургашын болытлар.* Р.Батулла

5) Фаҗигале. *Ике гасыр дәвамында басылган татар китабын юкка чыгару – әнә шуның аяныч, трагик мисалы.* Ә.Кәримуллин. *Факил Сафинның 1917 елгы түнтәрелешләргә һәм шуннан соңгы зур һәм трагик тарихи процессларга багышланган романы «Саташып аткан таң» дип атала.* Ф.Урманчеев

**ТРА́ГИК** II *и. гр.* 1) Фаҗигале рольләрне уйнаучы артист амплуасы. *Бер заман сезне Кавказның бөек трагигы Араблинский үз театрына күтәреп алып китә язды.* Н.Исәнбәт. *Трагик Мохтар Мутинны гайрәтле актёр булган дип сөйлиләр.* Р.Батулла

2) Трагедия (*1 мәгъ.*) язучы

**ТРА́ГИКЛЫК** *и.* Әсәрдәге трагедия элементлары, темасы, төсмере; фаҗигалелек. *«Алмачуар» поэмасындагы гүзәллеге белән трагик, трагиклыгы белән гүзәл ат язмышы кызыксынуым сусынын көчәйтте генә ---.* Р.Харис. *Шуңа күрә аерым шәхес фаҗигасенә ул тарихи мәгънә бирә, трагиклык аның шигырьләрендә бөеккә, күтәренкегә күчә.* Э.Галиева

**ТРАГИКОМЕ́ДИЯ** *и. гр.* 1) Трагедия һәм комедия элементларын эченә алган драма әсәре. *Мөхәррир әфәнде, бу трагикомедиянең ахырына барып чыгарга теләпмедер, хатны язарга утырды, бик тиз арада язып, Тимерша байга тоттырды.* Х.Кәрим. *Автор аны трагикомедия дип тә, сагышлы комедия дип тә атап караган, автор белән бәхәсләшергә дә булыр иде, Азат Әхмәдуллин аны мелодрама дип атады.* Р.Батулла

2) Бер үк вакытта кызганыч та, көлке дә булып тоелган вакыйга, хәл. *Сиңа мондый трагикомедия күрү бик кызык тоела торгандыр?* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Бу трагикомедия бер Әлбинә язмышына гына карамый.* Ф.Хөсни

**ТРАГИКО́МИК** *с.* 1) Трагикомедияләрдә була торган, шуңа хас. *Аңа драматик, трагикомик образлар да, психологик яисә комик образлар да җиңел бирелә.* Р.Миңнуллин

2) Бер үк вакытта көлке дә, фаҗигале дә булган. *Шулай итеп, карт көлке дә, кызганыч та, ягъни трагикомик хәлдә кала.* Татар әдәбияты. *50 дән артык тасмада төшкән ир-егетне күп режиссёрлар гениаль трагикомик актёр дип таный ---.* Тамаша

**ТРАДЕСКА́НЦИЯ** *и. лат. бот.* Коммелиначалар семьялыгыннан бүлмә гөле булып үстерелә торган зәңгәр яки кызыл чәчәкле, вак кына яшел шома яфраклы үсемлек. *Ә традесканцияләр арасыннан эре, «итләч» яфраклылары аеруча зур савыктыргыч көчкә ия.* Ватаным Татарстан. *Гөл утыртканда Игезәкләр фикус, пальма, традесканциягә өстенлек бирсен.* Шәһри Казан

**ТРАДИЦИОН** *с.* 1) Традициягә нигезләнгән, буыннан буынга күчеп килгән; гадәт, традиция булып әверелгән. *– Сэр мастер, сезнең фермада нинди технология кулланышта булды: Канаданыкымы, Голландиянекеме? – Икесе дә булды: әбинеке дә, бабайныкы да! Әби-бабайлардан калган традицион ысул дип атала ул.* М.Юныс. *Ул – дистәләрчә әкиятләр авторы, әкиятләре традицион стильдә, традицияләрдән чыгу очраклары да бар.* Р.Батулла

2) Традиция буенча була торган. *Кыргызстан татарлары өчен Сабан туе – традицион бәйрәм, һәм милләттәшләребез аны ел саен оешкан төстә үткәреп килә.* Казан утлары. *Аңа традицион бүләк – тәкәгә өстәп «Фиат» җиңел автомобиле дә бирелде.* Татарстан яшьләре

3) Гадәти, гомум кабул ителгән. *Традицион әдәп кагыйдәләре дә [сагызны] хуп күрми.* М.Әмир. *Радик абый, Яңа ел төне алдыннан традицион сорау: киләсе елга нинди өметләр баглыйсыз?* Шәһри Казан

**ТРАДИЦИО́НЛЫК** *и.* 1) Традицион булу; гадәтилек

2) Традицияләргә, гадәттә аларның онытыла барганнарына яки консервативларына тугрылык. *Безнең халыкта традиционлык бик көчле: әгәр ике-өч ел газета-журнал алдырмаса, ул радиотелевидение белән канәгатьләнәчәк, газета-журналга әйләнеп тә карамаячак.* Р.Миңнуллин. *Болгарда урнашкан мавзолейларда, нигездә, традиционлык – катгый шәригать кануннары белән җирләнү сакланган ---.* А.Шәймәндәр

**ТРАДИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Яшәү рәвеше, иҗтимагый карашлар нигезендә барлыкка килеп, буыннан буынга күчә торган гореф-гадәтләр, әхлак кагыйдәләре, карашлар, зәвыклар һ.б.ш. *Табында хуҗа һәм кунакларның бербереннә матур теләкләр белән җыр әйтешүе һәм күмәк җыр – керәшен татарларының һәр төркеменә дә хас күренеш, ата-бабалардан калган матур традиция.* З.Кириллова. *X–XII гасырларда элеккеге чорда барлыкка килгән сәнгать традицияләре дәвам итә.* Татарстан тарихы

2) Көнкүрештә, үз-үзен тотышта урнашкан, гадәткә кергән тәртип, язылмаган закон. *Разведчикларның нинди дер язылмаган законнары, традицияләре бар.* Г.Әпсәләмов. *Баласы тугач, әтисенең табиб кесәсенә акча салуы бездә гадәти хәл, күптәнге традиция булып исәпләнә.* Ак калфак

**ТРАДИ́ЦИЯЛЕ** *с.* Үзенең традицияләре булган. *Безнең балалар әдәбияты – зур традицияле, күренекле әдипләре, татар совет әдәбиятының*

*алтын хәзинәсенә кергән әсәрләре булган бай әдәбият.* Р.Миңнуллин. *Бу үзе үк авылның тирән тамырлы, бай мираслы, мәгърифәтле, нык традицияле булуын күрсәтә.* Ф.Бәйрәмова

**ТРАДИ́ЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Дәвамчанлык, эзлеклелек, традиционлык. *Торак пункт атамаларының транслитерациясе һәм транскрипцияләү барышында традициялелек зур кыенлыклар тудыра.* Л.Шәрифуллина. *Ул әдәбиятны төрле яктан: конфликт мәсьәләсен, әсәрнең төзелешен, образлар системасын, тел-сурәтләү чараларын форма, эчтәлек, көчемлелек һәм традициялелек ноктасыннан өйрәнә.* Татар әдәбияты

**ТРАЕКТО́РИЯ** *и. лат. махс.* 1) Хәрәкәт итә торган җисемнең пространстводагы юлы. *Башмак тоткан кул яшен тизлеге белән һаваны ярып баш өстенә күтәрелде, яулык күзләрне каплап бетерде дигәндә генә, тиешле траектория буйлап шапылдатып китереп тә сукты.* Җ.Юныс. *Әмма төкерек һавада матур гына траектория белән очып барганда, почмактан директор килеп чыккан, һәм... калганын сөйләү түгел, күз алдына китерүгә үк аркалар чымырдый башлый.* А.Гыймадиев

2) *хәрби* Снаряд, мина, торпеда, ракета, пуляның очыш юлы

**ТРАЙРА-РАЙ** *ы.* Бик кәефле, шат күңелле булганда, көйләп, тантаналы рәвештә әйтелә. *Сыздырыйк инде җиңү маршын шулай, Сыз, кураем, трайрарай да трайра-рай!* Н.Исәнбәт

**ТРАК** *и. ингл. тех.* Танк, трактор һ.б.ш.да тәгәрмәч чылбырының бер буыны

**ТРАКТ** *и. лат.* 1) Олы юл. *Оренбург трактының шәрә кырында «Газик» тукталып калды.* Ф.Яхин. *Авыл олы юл – Казаннан Пермьгә бара торган тракт буенда урнашканлыктан, анда яшәгән халыкның тормышы тынгысыз булган.* Гасырлар авазы

2) Кешеләрдә һәм башка җан ияләрендә ашаган ризыкның кереп эшкәртелеп, үзләштерелеп узу юлы. *Ашказан-эчәклек трактының эшчәнлеген яхшырта, йөрәккә ярдәм итә, организмдагы холестеринны киметә, артериаль кан басымын җайга сала.* Ватаным Татарстан *Ашкайнату тракты имезүчеләргә генә хас итчел иреннәр, яңаклар һәм казналыклар арасында урнашкан авыз алды куышлыгыннан яки авыз алдыннан башлана.* Биология.

**ТРАКТАТ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса зур мәсьәләне, проблеманы тикшергән фәнни хезмәт. *Әйтик, биш яшьтә мәхәббәт турында трактат язган бер бала бар.* Р.Батулла. *Бүлек фондында аеруча кызыклы кульъязмалардан билгесез автор тарафыннан 1845 елда иҗат ителгән фәлсәфи трактат характерындагы «Мәгарифе кальбият» исемле күләмле шигъри әсәрнең дә күчермәсе бар.* Гасырлар авазы

2) *махс.* Халыкара шартнамә, килешү. *Сугыштан соң ике дәүләт арасында төзелгән сәүдә трактаты --- төрки теленә күчерелеп, 1783–1784 елларда Петербургта басылган.* И.Рәмиев. *Федераль советның трактатларны гына килешеп куярга [хакы] бар.* Г.Коләхмәтов

**ТРАКТИР** *и. пол. иск.* Түбән дәрәҗәдәге ресторан; кабак. *Менә заводлар, трактирлар, пивнойлар, ночлежный домнар, койма аслары, төрмәләр – һәммәсе бергә капма-каршы!* Ш.Камал. *Ул мәхәлләдәге Влахер сарае тирәсендәге трактирларда гына ишетергә була иде кала халкының гайбәтен ---.* М.Хәбибуллин

**ТРАКТИРЧЫ** *и. иск.* Трактир хуҗасы, трактир тотучы кеше. *Трактирчы, өстәлне сөртеп алып, --- ике агач җамыяк белән өстендә колмаклары һәм сарымсаклары йөзеп йөргән өй сырасы һәм зур чүлмәк кружка белән кумышка китереп куйды.* М.Гали

**ТРАКТО́ВКА** *и. рус сәнг.* Берәр вакыйга, күренеш һ.б.ш.га язмача яки телдән аңлатма бирү, билгеле бер рәвештә якын килү, ачу формасы. *Эш авторның материалны уңышлы эшләвендә генә яисә артистларның яхшы уйнауларында гына түгел, бәлки режиссёрның табигый мизансценалар белән тиешле трактовканы бирә белүендә дә ---.* М.Җәлил. *«Һәрбер коммунист яхшы сәүдәгәр дә булырга тиеш» – Ленин сүзләренең иркле трактовкасы.* Һ.Такташ

**ТРАКТО́ВКАЛАУ** *ф. сәнг.* Берәр күренеш, вакыйганы билгеле рәвештә аңлату, образны билгеле рәвештә ачу. *«Изге әманәт»не сәхнәгә куйганда, режиссура аны трагедия итеп трактовкаламады.* Б.Гыйззәт. *Кыскасы, кырмыска үз дәрәҗәсен, үз кадерен бик тә яхшы белә. Акмулла да бу образны шушыңа якын рәвештә трактовкалый.* Х.Мәхмүтов

**Трактовкалап карау** Трактовкаларга тырышу

**ТРА́КТОР** *и. лат.* Авыл хуҗалыгы коралларын яки башка төр коралларны хәрәкәткә китерә торган һәм зур тарту көченә ия булган үзйөрешле авыр машина. *Ә сабаннарның үзләрен ат урынына тракторларга беркетеп, тракторлардан сабан сөрдерәбез.* М.Җәлил. *Үз төтененә үзе күмелгән трактор, арты белән чигенә-чигенә, территория читендәге зур чүплеккә таба китте.* Ф.Баттал

**ТРАКТОРИСТ** *и. рус к.* **тракторчы**. *Җыйнак кына түгәрәк табында тракторист Фәнәви белән мәктәпнең тарих укытучысы Фатих абый янәшә утырганнар.* З.Зәйнуллин. *Инде аңа Хәлил улы колхозда тракторист яки шофёр булып күзалланмый, бәлки кимендә рәислек итәргә тиештер кебек тоела башлады.* Ф.Яхин

**ТРАКТОРИСТЛЫК** *и.* Тракторчы һөнәре. *Галимҗан сугыш алдыннан трактористлыкка укырга ниятләп йөри иде.* Р.Төхфәтуллин. *Ил-җир күргән (ни әйтсәң дә, авылдан ун чакрым ераклыкта, фатир торып, трактористлыкка укыган) Исламгали дә монысын аңламады.* М.Мәһдиев

**ТРА́КТОРЛАШТЫРУ** *ф.* Халык хуҗалыгының кайсы да булса тармагында тракторлар белән эш итүгә күчү; халык хуҗалыгының берәр тармагын җитәрлек дәрәҗәдә тракторлар белән тәэмин итү. *Чөгендер игүне тулысынча тракторлаштыру*

**Тракторлаштыра башлау** Тракторлаштырырга керешү

**Тракторлаштырып бетерү** Тулысынча тракторлаштыру

**ТРАКТОР-МАШИНА** *җый. и.* Һәртөрле трактор һәм машиналар. *Авылда*

*бер генә чат та, трактор-машина паркы да калмады инде без актарынмаган.* Д.Гайнетдинова. *Ә Фираяның күңелендә иң онытылмас хатирә булып калганы менә нәрсә иде: авылның трактор-машина ремонтлый торган мастерскоена барып, --- тумбочка сымак нәрсә эшләтеп алып кайтты.* Д.Бүләков

**ТРА́КТОРЧЫ** *и.* Трактор йөртүче. *Аның ире тракторчы иде, сугышка җибәрмичә тордылар.* Ә.Гаффар. *Әлеге авыр итекләр бертуктаусыз идәннән ут чыгара... «Шап-шап-шап»! Болар – безнең тракторчы кызларыбыз.* Ф.Баттал

**ТРА́КТОРЧЫЛЫК** *и.* Тракторчы булу, тракторчы һөнәре. *Атлар белән хыялланып үссә дә, алар тракторчылыкка укый ---.* Р.Рахман. *Егетлек чорына кергәч, тракторчылыкка укыдым да 40 ел буе рәттән «тимер айгыр»ыннан төшми эшләдем.* Казан утлары

**ТРАЛ** *и. ингл.* 1) Суднодан торып диңгез балыкларын тоту өчен кулланыла торган зур ятьмә. *Су төбендәрәк яшәүче балыкларны тоту өчен --- трал кулланалар.* Зоология. *Өр-яңа капрон тралның җете ак калкавычлары болганчык су өстендә әзрәк күренеп барырга да өлгермәделәр, күздән югалдылар.* Казан утлары

2) *хәрби* Су асты миналарын тоту һәм зарарсызландыру өчен махсус җайланма; мина аулагыч. *Сугыш чорында Яшел Үзән каласының Горький исемендәге судноларт төзү заводы Идел хәрби флотилиясенә --- 9 трал буксиры һ.б. техника озата.* Шәһри Казан. *10 июльгә 3 эсминец, --- 11 су асты көймәсе, 5 трал, 5 торпеда катеры һәм башка хәрби судноларт тар-мар ителә.* Кызыл таң

**ТРАЛЛА́У** *ф.* Трал белән балык, су хайваннары яки миналар тоту. *Су төбендәге магнитлы мина безнең арттан килүче траллау баржасын шартлатырга тиеш.* С.Сабиров

**Траллап бетерү** Траллау эшен тәмамлау

**Траллап чыгу** Башыннан ахыргача траллау

**Траллый башлау** Тралларга тотыну

**ТРАЛ-ЛӘ-ЛӘ** *ы.* Берәр нәрсәгә шатланганда, күңел күтәрелгәндә җырлана. *Шулай трал-лә-лә дип чибәрләнеп торганда, мин үземне: «Галия, боларны бит син Искәндәр өчен эшлисең», – дигән фикердә тоттым.* Г.Кутуй

**ТРАЛ-ЛӘ-ЛӘМ** *ы. к.* **трал-лә-лә**. *Үкчәңне күтәр, хәшәрәт, Юк итәрбез, кабахәт. Трал-лә-ләм, Трал-лә-ләм, үкчәңне күтәр, хәшәрәт, Юк итәрбез, кабахәт.* М.Мәһдиев

**ТРАЛ-ЛЯ-ЛЯ** *ы. к.* **трал-лә-лә**. *Премия алдык! Трал-ля-ля! Трал-ля-ля!* Г.Ахунов

**ТРАЛЧЫ** *и. к.* **тральщик**. *Тралчылар командиры --- каш астыннан миңа ризасыз карап нервылана башлады: «Монда юк минаны эзләп су сукалауда ни мәгънә?»* С.Сабиров

**ТРА́ЛЬЩИК** *и. рус* 1) Трал (*1 мәгъ.*) белән җиһазландырылган балык тоту судносы. *Шул арада бер тральщик порттан чыгып китте.* А.Таһиров. *Тральщиклар флоты*

2) Трал (*1 мәгъ.*) белән балык тотуга җитәкчелек итүче кеше. *Тәҗрибәле тральщик кул астында эшләү*

3) Су асты миналарын трал (*2 мәгъ.*) белән тота торган хәрби корабль. *Гөрселдәп шартлау дулкыны һаваны тетрәтте. Берничә минуттан без көймәдә барып җиткәндә, --- капитан күперчегендә тральщик командиры, бинокләен як-якка юнәлтә-юнәлтә, су өстендә нидер эзли иде.* С.Сабиров. *Бу зур бәйрәмне өйләрендә дә, Берлинда да түгел, ә үзләренең нәни корабларында – тральщикта каршылаган.* Идел

4) Шундый корабльдә хәрби минёр

**ТРАМВАЙ** *и. ингл.* 1) Электр көче белән тимер юлдан йөртелә торган шәһәр транспортының бер төре. *Якындагы трамвай будкасын кар күбәләкләре сырып алган.* К.Нәҗми. *Парижда елына 280 миллионлап трамвай билеты [сатыла иде].* Г.Гали

2) Шул юлда йөри торган бер яки берничә вагонлы поезд. *Трамвайга кергәннән бирле, юл буе бу ике «бажай» Шәмсинең имгәнү һәм аяксыз калу тарихын фаразлап бардылар.* Ж.Юныс. *– Беләсеңме, Казан – матур шәһәр, ләкин безнең Әстерханга җитми инде, – диде Чулпан, шак-шок килгән трамвайда кайтканда.* Х.Ширмән

**ТРАМВАЙЧЫ** *и.* Трамвай йөртүче яки трамвай паркында эшләүче кеше. *Сәйфуллин --- малайны үзе белән ияртеп китте, трамвайчыларга дип атап салына торган йортны күрсәтте ---.* А.Гыйләҗев. – *Ун чакрымнан артык утырып кайтып та өч тиен җәлләсәң, йөзеңә төкерсә дә, трамвайчы хаклы булыр, – дим, кассага таба омтылып.* Ф.Баттал

**ТРА́М-ПАМ** *иярт.* Тантаналы марш уйнаганда яки көйләгәндә чыга торган өзек-өзек тавышны белдерә. – *Туктагыз, булмаса, мин үзем... трам-пам, трам-пам... – дип, полковник җиңел генә марш көйләп, баскычтан менеп китә.* Ә.Фәйзи

**ТРАМПАРК** *и. рус* Трамвай вагоннары кереп туктый яки ремонтлана торган урын. *Трампарк каршында иске чиркәү бар.* М.Маликова. *Тоттым да беренче трампаркка киттем.* А.Хәсәнов

**ТРАМПЛИН** *и. фр.* 1) Сикерү еракльгын яки биеклеген арттыру өчен эшләнгән махсус таусыман корылма яки ясалма калкулык. *Тугызынчы класс малайларын таудан шуарга өйрәтәсе бармы, өйрәтелсә, нинди алымнарга өйрәтелә? Трамплиннан сикерергәме? Таяклар утыртып куеп, шулар арасыннан бормалап шуаргамы?* М.Мәһдиев. *Без синең кебек чакта яр өстеннән суга да чума идек, чаңгы белән трамплиннан да мәтәлә идек.* Р.Кәрами

2) Трамплинны (*1 мәгъ.*) хәтерләткән табигый биеклек. – *Карагыз, иптәш гвардия капитаны, нинди коточкыч трамплин, – диде командирларның берсе. Мин түбәнгә карадым. Тау чыннан да текә.* Г.Әпсәләмов. *Тәвәккәл таш яра, дип, үз-үземә дәрт өстәгәндә, мин инде бөкшәя төшеп, ике таягымны да артка чөеп, трамплинның сыртына якынлашып килә идем.* К.Миңлебаев

3) *күч.* Нинди дә булса эш-гамәлләр өчен таяныч, башлангыч пункт; алга китү өчен әйбәт ярдәм иткән фактор. *Бу [эш] сиңа югарырак сикерү өчен трамплин булырга тиеш.* Х.Вахит. *Бүген Салават Фәтхетдинов җитәкләгән «Салават» җыр театры яшь башкаручылар өчен трамплин булып тора.* Тамаша

**ТРАМ-ТАРАРА́М БУЛУ** *ф. к.* **трам-тарарам килү**

**ТРАМ-ТАРАРА́М КИЛҮ** *ф.* Нәрсәнең дә булса тәртибе, системасы бөтенләй бозылу, таркалу, чуалу, буталу. *Бөтен дөньяның тезгене бухгалтерлар кулында, алар шул тезгенне ычкындырып җибәрсәләр, дөньяның асты өскә киләчәк, бөтен банклар трам-тарарам булачак.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ТРАМ-ТЫРАГА́Й БУЛУ** *ф. к.* **трам-тырагай килү**

**ТРАМ-ТЫРАГА́Й КИЛҮ** *ф.* 1) Төрле урынга таралу, сибелү, таркалу, китү. *Хәзер берегез анда, берегез монда трам-тырагай булып йөрисез бугай.* М.Гафури

2) *күч.* Таркалу, юкка чыгу, бозылу. *Эштә трам-тырагай башлану*

**ТРАНЗИ́СТОР** *и. ингл.* 1) Радиотехникада, электроникада, телемеханикада һ.б.ш.да электр сигналларын көчәйтә, үзгәртә торган өч электродлы ярымүткәргечле прибор. *Трансформатордан бинага баручы калын чыбык тышкы кыяфәте белән цилиндрны хәтерләтүче билгесез предмет аша үтә иде, эксперт транзисторны келәшчәсе белән җәһәт кенә ике башыннан өзеп алды.* Ф.Бәллүр

2) Шундый приборлы портатив радиоалгыч. *Бер хатын бала арбасы этеп бара, ә янында ире, аның кулында транзистор.* Р.Кәрами. *Ә туйдагы яшьләрнең ничәсендә генә транзистор бар.* М.Мәһдиев

**ТРАНЗИ́СТОРЛЫ** *с.* Транзистор (*1 мәгъ.*) ярдәмендә эшли торган. *Транзисторлы радиоалгычларның әле күренә генә башлаган чагы.* А.Хәсәнов. *Тәрәзә төпләрендә транзисторлы радиоалгыч, бер китап аунап ята.* Р.Кәрами. *Хәзер инде аларны транзисторлы радиоалгычлар гына канәгатьләндерми, күпләп газета-журналлар алдыралар, хатлар язалар ---.* Д.Бүләков

**ТРАНЗИТ** *и. лат.* **1.** 1) Бер илдән икенче илгә арадагы өченче ил аркылы яки бер пункттан икенче пунктка арадаш пунктлар аша юлчылар һәм товарлар ташу формасы. *Өйгә кайтасын уйлагыз. Транзит белән Магаданга алып китмәсеннәр, [диде курсант].* З.Мәхмүди. *Меркель транзит операцияләрен туктату турында карар кабул иткән.* Ватаным Татарстан

2) Йөкне бушатмыйча арадагы пунктларда бер урыннан икенче урынга күчерү формасы. *Русия Әфганстанга хәрби булмаган товарларны транзит итәргә килешкән.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул ысулга нигезләнгән. *1906 – 1924 еллар. Ул Көнчыгыш һәм Көнбатышның транзит сәүдәсе үзәге булган.* И.Хуҗин

2) Шундый хокук бирә торган. *Финляндия аңа берничек тә виза бирә алмый, шунлыктан С.Максуди, анда виза алу мөмкинлеген ишетеп, Стокгольмга килә, аннан транзит виза белән Германия аша Парижга китә.* Гасырлар авазы. *Беларусьның әллә ни табигый ятмалары юк, ләкин ул Русия белән Европа арасында транзит ил санала.* Ватаным Татарстан

3) Билгеләнгән урынга кадәр транзит белән бара торган; транзит юлы белән башкарыла торган. *Шуңа күрә вокзалның залына кереп, транзит рейсны көтәргә булдык.* М.Хәсәнов. *Транзит поездлар аеруча куркыныч: алар ничек югары тизлектә килсәләр, шулай узып та китәләр.* Шәһри Казан

4) Аэропортта, вокзалда бер поезддан, самолёттан һ.б.дан икенче поездга, самолётка һ.б.ш.га күчеп утыру. *Варис хатынын гомер буе транзит пассажир итмәү хәстәрен күрә башлады.* М.Хәсәнов. *Шәһәре, синагогалары, мәчетләре, чиркәүләре, галәмәт зур базарлары, анда сатылучы коллары белән сәяхәтчеләрне һәм транзит мөселман сәүдәгәрләрен шаккатыра.* Ватаным Татарстан

5) Шундый пассажирлар өчен билгеләнгән. *[Ул], транзит вагоннарына таратылган --- шпиклардан шикләнәшикләнә, МОПР значогы чыгара.* Г.Гали. *2013–2015 елларда исә беренче булып Халыкара конгресс-күргәзмәләр үзәге (транзит отельләр һәм офис үзәкләре белән бергә) белән махсус икътисади зона сафка басачак.* Шәһри Казан

6) Билгеләнгән пунктка кадәр бер вагоннан икенчесенә бушатылмый үткәрелә торган. *Транзит йөк*

**ТРАНС-** *лат.* 1) Кушма сүзләрдә «берәр ил, территория, пространство аша йөри, үтә торган» мәгънәсен белдергән беренче кисәк (мәс., *трансконтиненталь, трансарктик, трансатлантик*)

2) Кушма сүзләрдә «берәр нәрсәдән соң, берәр нәрсә артында булган» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *трансуран элементлар*)

**ТРАНСА́РКТИК** *с.* Арктика аша үтә торган. *Болар – 2012 елда 14 номинациядә «Рус географик җәмгыяте» иҗтимагый әһәмияттәге проектлар эшләгән өчен грантлар бирү, «Путь Ориона» бөтендөнья трансарктик экспедициядә катнашучы кадет-укучыларга дипломнар тапшыру ---.* Чистай хәбәрләре

**ТРАНСАТЛА́НТИК** *с.* Атлантик океан аша йөри торган. *Берничә елдан, 1972 елның 15 маенда «Кунард – Лайн» компаниясенең «Куин Элизабет – 2» лайнеры 1514 пассажир һәм 900 кешелек экипаж белән трансатлантик рейска чыга.* Татарстан яшьләре

**ТРАНСВЕСТИЗМ** *и. лат.* Кешенең үз-үзен капма-каршы җенестәге кебек хис итүе, үзен шулай тоту күренеше

**ТРАНСВЕСТИТ** *и. ингл.* 1) Үз-үзен капма-каршы җенестәге кеше кебек тотучы

2) Хирургик операция ярдәмендә үз җенесен капма-каршы җенескә үзгәрткән кеше

**ТРАНСКОНТИНЕНТАЛЬ** *с.* Континент аша үтә торган. *Аргентинада «Дака – 2012» трансконтиненталь марафонының III этабы тәмамланды.* Татарстан яшьләре. *Көньяк Америка кыйтгасында үткән быелгы «Дакар» трансконтиненталь ралли марафоннар тарихында 34 нчесе булды.* Әлмәт таңнары

**ТРАНСКРИПЦИОН** *с.* Транскрипциягә нигезләнгән, транскрипция өчен хезмәт итә торган. *Транскрипцион билге. Транскрипцион система*

**ТРАНСКРИ́ПЦИЯ** *и. лат.* 1) *лингв.* Нинди дә булса тел яки диалект авазларын, бу телнең язу системасыннан үзгәрәк булган хәрефләр, шартлы билгеләр белән бирү; шундый

билгеләр системасы. *Табышмакларның язылышында диалект һәм урынчылык аермалары сакланмады. Алар фәнни транскрипция буенча да бирелмәде.* Н.Исәнбәт. *Әгәр без транскрипция системасын кабул итсәк, татар теле имласы 50 – 60 билгедән торачак.* Ә.Кәримуллин

2) *муз.* Берәр музыка коралы яки билгеле бер тавыш өчен язылган әсәрне икенче бер инструментта уйнау яки икенче тавыш өчен үзгәртеп язу. *«Сәйдәшстан» циклы музыканы тар мәгънәсендә транскрипцияләү түгел, ә музыка фәненә нигезләнеп авторлаштырылган транскрипция.* Шәһри Казан

**ТРАНСКРИ́ПЦИЯЛӘҮ** *ф. лингв.* 1) Транскрипция ясау, сөйләмне махсус билгеләр ярдәмендә язуда беркетү

2) *муз.* Музыка әсәренә транскрипция ясау

**Транскрипцияләп бетерү** Транскрипцияләүне төгәлләү, тәмамлау

**Транскрипцияләп карау** Транскрипцияләргә омтылу, транскрипцияләргә тырышу

**Транскрипцияли башлау** Транскрипцияләргә тотыну

**ТРАНСЛИТЕРА́ЦИЯ** *и. лат. лингв.* Бер язу системасы хәрефләрен икенче язу системасы хәрефләре белән алыштырып язу. *Торак пункт атамаларының транслитерациясе, аларны транскрипцияләү принципларын бирүдә беренче адым 1966 елда чыккан «Татарча-русча сүзлек»тә ясала.* Л.Шәрифуллина. *Энциклопедиядә кабул ителгән «Шәрекъ» язылышы – транскрипциясе, әллә транслитерациясе – аңламассың, ләкин һәрхәлдә бу вариант татарча язылыш була алмый.* Гыйлем хәзинәсе

**ТРАНСЛИТЕРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Транслитерация ясау

**Транслитерацияләп бетерү** Транслитерацияләүне тәмамлау, төгәлләү

**Транслитерацияләп карау** Транслитерацияләргә тырышу

**Транслитерацияли башлау** Транслитерацияләргә керешү

**ТРАНСЛЯ́ТОР** *и. лат.* 1) *тех.* Тавыш, сурәт һ.б. төрле мәгълүматны белдерә торган электрик элемтә сигналларын көчәйтү, үзгәртү һәм тапшыру өчен арадаш радиотехник җайланма. *Аннары трансляторыбызны --- «Спорт – 2», «НТВ» каналларының берсенә көйләргә тырышып йөрдек.* Татарстан яшьләре. *Барлык район үзәкләре дә якындагы трансляторлардан цифрлы тапшырулар кабул итәчәк.* Минзәлә

2) *информ.* Трансляция (*3 мәгъ.*) ясау программасы. *Транслятор теләсә кайсы программалау системасының мәҗбүри элементы булып тора.* Фән һәм тел. *Автокод, Паскаль, Фортран һәм башка телләрне машина теленә күчерә торган программа тәрҗемәче транслятор дип атала.* Информатика

**ТРАНСЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса эш-хәрәкәт яки вакыйга булган урыннан радио- яисә телетапшыру алып бару эше. *Хәзер бит --- күп кенә концертлардан, Сабантуйлардан, башка күңел ачу урыннарыннан трансляцияләр бара.* Р.Миңнуллин. *Моңарчы күз алдына да китереп булмаган турыдан-туры элемтәләр, яшь тамашачылар өчен ток-шоулар, җыр бәйгеләре, бәйрәм трансляцияләре үтеп керде.* К.Кәримов

2) Шундый юл белән тапшырыла торган хәбәрләр, әсәрләр

3) *информ.* Бер программалау телендәге программаны икенче программалау телендәге эквивалент программага күчерү, үзгәртү

**ТРАНСЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Трансляция ясау. *Шигырь бәйрәмен ул елларда телевизор аша турыдан-туры трансляцияләү юк, бары тик кичләрен кыскартылган репортажлар гына бирәләр иде.* Ф.Яруллин. *Узган ел бөек җырчыбыз Илһам Шакировның юбилей кичәсен бөтен дөньяга трансляцияләдек.* Р.Фәйзуллин

**Трансляцияләп бару** Бер-бер артлы, эзлекле рәвештә трансляцияләү. *«Яңа гасыр» каналы киләсе телевизион сезонда «Баскет-холл»да узган бу ярышларны атна саен трансляцияләп барачак.* Татарстан яшьләре

**Трансляцияләп килү** Эзлекле рәвештә, күптәннән бирле трансляцияләү

**Трансляцияләп тору** Даими яки хәзерге вакытта трансляцияләү. *Яңа музыкаль телеканал моның өчен бөтен шартларны тудырып, турыдан-туры трансляцияләп торды.* Шәһри Казан

**Трансляцияли башлау** Трансляцияләргә тотыну

**ТРАНСМИ́ССИЯ** *и. лат.* 1) *тех.* Хәрәкәтне двигательдән станокның яки машиналарның эшләп торган частьларына тапшыра, күчерә торган барлык механизмнар системасы. *Тугәмгә сыенып трансмиссияләр әйләнә, алардан станокларга каешлар сузылган.* Г.Әпсәләмов. *Безнең республикада --- трансмиссияләрне, тәрәзә күтәрткечләр, кузов детальләрен җитештерү өчен мөмкинлекләр җитәрлек.* Гасырлар авазы

2) *күч.* Күчеш, күчүчәнлек; тапшыру. *Тикшеренүчеләр этномәдәният трансмиссиясендә гаилә әгъзалары арасында рольләр бүленешенең аерым үзенчәлекләре булуын билгеләп үтәләр.* Сөембикә

**ТРАНСПАРАНТ** *и. фр.* 1) Рамга алынган яки ике таякка беркетелгән, берәр лозунг язылган яки сурәт төшерелгән кәгазь, тукыма. --- *ике минут урынына ике сәгать кайнаган художниклар «Долой аракы!» дигән транспарант күтәреп чыкканнар.* Ф.Баттал. *Тамаша башлану церемониясе алдыннан махсус бер кеше, транспарант күтәреп, үгезнең авырлыгын, нәселен, исемен белдерә.* Р.Фәйзуллин

2) Язганда, юллар туры булсын өчен, сызыксыз чиста кәгазь астына куела торган кара сызыклы каты кәгазь

**ТРАНСПЛАНТАТ** *и. лат. биол.* Икенче урынга яки икенче организмга күчерү өчен файдаланыла торган орган яки күзәнәк. *Узган ел бүлектә донор бөерен сигез дистанцион эксплантацияләү үткәрелә, беркетмә өчен, бөер трансплантатларын диагноз кую максатыннан кисеп алу гамәлгә кертелә.* Ватаным Татарстан

**ТРАНСПЛАНТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *мед.* Орган яки күзәнәкләрне бер урыннан икенче урынга, бер организмнан икенче организмга күчереп утырту эше. *Мондый авырулар исемлегенә туберкулёзның актив формалары, --- эчке органнарга яки сөяк миенә ясалган трансплантация очраклары, бөерләр-*

*нең каты авыртуы һәм башкалар кирә.* Ватаным Татарстан. *Сүз кеше органнарын башка кешегә күчереп утырту, ягъни трансплантация турында бара.* Татарстан яшьләре

2) *а.х.* Бер үсемлек кисәген яки бөресен икенче үсемлеккә күчерү; ялгау

**ТРАНСПЛАНТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Трансплантация ясау, күчереп кую. *Трансплантацияләү --- ярдәмендә, җәрәхәтләнү аркасында кан үтеп йөри алмаган тамырларны урап үтү өчен, яңа кан юллары ясала.* Я.Шәфыйков. *Бүген яралгыларны трансплантацияләү сыерларны ясалма орлыкландыруда киң кулланыла торган иң заманча ысул санала.* Мәдәни җомга

**ТРАНСПЛАНТО́ЛОГ** *и. лат.* Орган яки күзәнәкләрне күчереп утыртучы белгеч, табиб. *Операция җитәкчесе, трансплантолог Эдгар Бимер әйтүенчә, авыруга савыгу өчен әле озак вакыт физиотерапия үтәргә туры киләчәк.* Ватаным Татарстан. *Шуларның берсе (минем бакча күршем) – исеме бөтен илгә билгеле булган трансплантолог, медицина фәннәре докторы, профессор, бәвел чыгару органнарына пластик операцияләр ясаучы Идел буендагы бердәнбер белгеч Ринат Харис улы Галиев.* Татарстан яшьләре

**ТРА́НСПОРТ** *и. лат.* 1) Халык хуҗалыгының бер урыннан икенче урынга йөкләрне ташу яки пассажирлар йөртү белән шөгыльләнә торган тармагы, шулай ук күчерү чараларының теге яки бу төре. *Флүр Сәхәбиевич, --- транспортта йөрүне өнәмәсә дә, кызны артык кыстамады.* Р.Кәрами. *Ашлык амбары ягыннан, биш ат белән алты-җиде үгезгә ашлык төяп, транспорт бригадасы килеп төште.* Г.Бәширов

2) Йөкләр һәм кешеләр ташый торган хәрби судно. *Бүген төнлә порттан чыгарга әзерләнгән хәрби транспортларның да икесен батырып киттеләр.* Г.Кашшаф

3) Махсус максатлар өчен кулланыла торган олау яки башка төрле ташу чаралары. *Вахтага бару-кайту өчен бердәнбер җайлы транспорт булган вертолёт тәкъдим ителде.* Ш.Бикчурин. *Транспорт самолётлары һәр төн саен азык-төлек һәм сугыш кирәкләре ташыйлар.* Ш.Маннур

4) Бер урыннан икенче урынга илтү өчен билгеләнгән яки күчерелгән йөкләр партиясе, кешеләр төркеме. *Лагерьдан транспорт бик еш китеп тора. Кайбер транспортларда меңәрләгән кешеләр була.* Г.Әпсәләмов

**ТРАНСПОРТЁР** *и. фр.* 1) Йөкләрне чикләнгән арага күчерү өчен, өзлексез хәрәкәт иткән, горизонталь яки бераз авыш тасма рәвешендәге механик җайланма, конвейер. *Транспортёр буйлап югарыга цемент күтәрелә.* Г.Әпсәләмов. *Алар пилорамаларның конструкцияләрен бераз үзгәрттеләр; каяндыр тасма транспортёр табып, аның катокларын файдаланып, пилорамалар астына бүрәнәләр бирүне механикалаштырдылар.* М.Хәсәнов

2) Авыр йөкләрне күчерү өчен, күп күчәрле махсус тимер юл платформасы

3) Бронетранспортёр. *Киң чылбырлы --- транспортёрлар да сазлыкка әйләнгән юлларда көч-хәл белән үтәләр.* Г.Сафиуллин

**ТРАНСПОРТИР** *и. фр.* Почмакларны үлчәү яки төзү өчен, градусларга бүленгән ярым түгәрәк белән линейкадан гыйбарәт сызым әсбабы. *Кысынкы почмак сызыгыз һәм аны транспортир ярдәмендә үлчәгез.* Алгебра. *Аудиториягә үзең белән линейка, калькулятор, транспортир алып керергә рөхсәт ителә.* Сабантуй

**ТРА́НСПОРТЧЫ** *и.* Транспортта (*1 мәгъ.*) эшләүче. *Югары урамнан транспортчылар килеп төшә.* Г.Бәширов. *Хезмәтенә җаваплы карашы, төгәллеге, техниканы яхшы белүе аны районыбызның иң алдынгы транспортчылары сафына китерде.* Г.Мөхәммәтшин

**ТРАНССЕКСУАЛ** *и. ингл.* Үзенең тумыштан килгән җенси барлыгыннан риза булмаган кеше

**ТРАНССЕКСУАЛИЗМ** *и. ингл.* Кешедә тумыштан ук каршы як җенескә хас сыйфатларга омтылу күренеше

**ТРА́НСФЕР** *и. лат.* 1) Рәсми килешү нигезендә кемне яки нәрсәне дә булса икенче урынга күчерү

2) Спортчының контракт белән бер клубтан икенчесенә күчүе. *Динияр Билалетдиновны кышкы трансферда «Рубин»га алып кайтуны Корбан Бердыев та беренче максат итеп куйган.* Р.Шакир. *«Рубин» быелгы сезонда Гришин, Филонов, Гарибян кебек футболчыларын трансферга куйган.* Татарстан яшьләре

2) Туристларны аэропорттан кунакханәгә, кунакханәдән аэропортка илтүдән гыйбарәт хезмәт күрсәтү төре. *Трансферга заказ бирү*

**ТРАНСФЕРТ** *и. фр.* 1) *фин.* Бер ил валютасын яки алтынын икенче илгә күчерү

2) *фин.* Кыйммәтле кәгазьләргә хокукны икенче затка күчерү

3) *юр.* Халыкара килешү нигезендә гражданнарны алмашу, автомат рәвештә гражданлыкны үзгәртү

4) Уенчының икенче клубка күчүе өчен алынган акча

5) *к.* **трансфер** (*1 мәгъ.*). *Икътисад өлкәсендә азмы-күпме хәбәрдар булучыларга мәгълүм: бюджетара трансфертлар ил төбәкләре бюджетларының тәэмин ителешен тигезләүдә мөһим инструмент санала.* Шәһри Казан. *Закон проектында муниципаль берәмлекләргә трансфертларны 85 процент күләмендә бүлү билгеләнгән.* Ватаным Татарстан

**ТРАНСФОРМА́ТОР** *и. лат.* 1) *махс.* Алмаш электр тогы көчәнешен үзгәртү өчен хезмәт итә торган аппарат. *Ул арада электр трансформаторы өстендә бер егет һәлак булды: салган баштан яланкул шуңа тотынган.* М.Мәһдиев. *Аңарда трансформатор гөжләве генә ишетелә иде.* А.Тимергалин

2) *сәнг.* Кыяфәтен (киемен, гримын һ.б.ш.ны) һәм тавышын бик тиз үзгәртеп, берничә роль уйный торган артист. *Ул заманны миңа еш кына трансформатор булырга да туры килә иде. Китапта ничә хатын-кыз роле бар, барысын да миңа бирәләр. Аларның барысын да бер төрле уйнап булмый, һәркайсының үзенчәлекләрен, аерымлыкларын эзләргә кирәк була иде.* С.Гыйззәтуллина-Волжская

**ТРАНСФОРМАЦИОН** *с.* Трансформация күренеше белән бәйле, шуңа караган

**ТРАНСФОРМА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *кит.* Бер кыяфәттән, формадан икенче кыяфәткә, формага күчеш; әверелеш. *Ватан образының трансформациясе шагыйрьнең дуслык хисен олылый, нәфислеген, сафлыгын сиздерә.* Г.Кашшаф. *--- тарихи Атилланың үлеме белән бәйле вакыйга шактый озын юл узып, XIII гасырга бөтенләй башка формада – исем трансформациясе аша килеп җитә.* Ф.Урманчеев

2) *физ.* Трансформатор (*1 мәгъ.*) ярдәмендә электр тогының көчәнешен үзгәртү процессы. *Трансформация аппаратурасы*

**ТРАНСФОРМА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Бер кыяфәттән, формадан икенче кыяфәткә, формага күчү; әверелү; үзгәрү. *Шигъриятә традицион символларның трансформацияләнүе, яңа эчтәлеккә ия күптөрле троплар барлыкка килү дә нәкъ менә бер гасыр элек күзәтелә.* Р.Харрасова. *Теге яисә бу текстның халык яшәешендәге вазифасын, традициясен, саклану һәм трансформацияләнү сәбәпләрен ачыклауга юнәлтелгән эзләнүләр дә кирәк.* Татар халык иҗаты

**Трансформацияләнә башлау** Трансформация процессының башы күзәтелү

**Трансформацияләнеп бетү** Тулысынча трансформацияләнү

**ТРАНСФОРМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Бер кыяфәттән, формадан икенче кыяфәткә, формага күчерү; әверелдерү; үзгәртү. *Туфан иҗаты өчен мәкаль һәм әйтемнәрне субституция (бер компонентны алыштыру) алымы ярдәмендә трансформацияләү хас.* Г.Әхмәдгалиева. *Димәк, бу әкияттә су трансформацияләү вазифасын үти, ягъни геройның кыяфәтен үзгәртә.* Татар халык иҗаты

**Трансформацияләп бетерү** Тулысынча трансформацияләү

**Трансформацияләп карау** Трансформацияләргә омтылу, тырышу

**ТРАНСФО́РМЕР** *и. ингл.* **1.** Аерым детальләрен сүтеп-җыеп яки боргалап, төрле рәвешләргә кертеп була торган уенчык-робот. *Бала-чага сканворд чишә, тетрис уйнады, ---- трансформерларын интектерде.* Д.Булатова. *Трансформер белән уйнау. Баласына трансформер алу*

**2.** *с. мәгъ.* Формалары үзгәрә, бер формадан икенчегә күчә, әверелә торган. *Трансформер залда күргәзмәләр, конференцияләр, очрашулар узачак.* Кызыл таң

**ТРАНТАЙ** *и. диал. к.* **торымтай**. *Туз чиләктә трантай уйный.* Табышмак

**ТРАНТАЙЛАНУ** *ф. диал.* Сикергәләү, кылану, чытлыклану. *Я әйдә, әйдә, егетләр тирәсендә күп трантайланып йөрмә!* М.Фәйзи

**Трантайланып алу** Бераз гына трантайлану

**ТРАНТАС** *и. сөйл. к.* **тарантас**. *Урманнан байтак җир киткәч, без үзебезгә таба трантас җиккән бер атлы килгәнен күрдек.* С.Җәлал. *Тимеркүк айгырын тыйды, без лакланган трантаска, атның чуклы эшлияләренә, җизләнгән күн йөгәненә исебез китеп катып калдык.* А.Гыйләҗев

**ТРАНШ** *и. фр. фин.* Күчерелергә тиешле зур сумманың бер алымда күчерелгән өлеше

**ТРАНШЕ́Я** *и. фр.* 1) *хәрби* Оборона позицияләрендәге барлык ут нокталарын тоташтыра, дошманга каршы ягына балчык, таш һ.б.ш. нәрсәләр өелгән һәм снаряд яки бомба кыйпылчыкларыннан саклану өчен хезмәт итә торган тар, тирән, озын чокыр. *Биленнән гранатасын суырып алып, траншея борылышына томырды.* Г.Әпсәләмов. *Немец кечкенә миномёттан атырга тотынды: траншеядагы сугышчыларның каскаларын шәйләгән ахры.* Х.Камалов

2) Берәр нәрсә күмү, салу, саклау һ.б.ш. максатлар өчен хезмәт итә торган озын тирән тар чокыр, канау. *Әллә ни тирән булмаган траншеяның як-ягында станоклар.* М.Хәсәнов. *Әүвәле һәркем үзенә чокыр казыды, аннары аларны үзара тоташтырып, траншея хасил иттеләр.* Ф.Яхин

3) *махс.* Тау токымнарын ачык ысул белән чыгару өчен казылган чокыр

**ТРАП** *и. голл.* 1) Суднодагы teләсә нинди баскыч. *Ишекне ачуга, кубрикка да су бәреп керә. [Хәйдәр], су ерып, югарыга чыга торган трапка омтыла.* Г.Әпсәләмов. *Шуннан соң ул өскә күтәрелү механизмнары янына шуышып барды, аларны эшләтеп җибәрде, аннары көч-хәл белән рубка трапына кайтты, люкка күтәрелде, көймә су астыннан чыккач, люкның капкачын ачты.* Казан утлары

2) Ярдан, причалдан судного күтәрелү яки төшү өчен махсус күчерелмә баскыч яки басма сыман җайланма. *Пристаньның икенче бер читендә, теплоходтан төшүчеләрне иплe генә күзәтеп, баһадир сынлы егет басып тора иде. Әлеге кыз трапта күренүгә үк, йөрәге җилкенеп тибә башлаган иде аның.* Р.Мөхәммәдиев. *Каерылып карасак, пароходтан ярга сузылган такта трапта, чынлап та, баһадирларча киң җилкәле бер солдат елмаеп тора --- иде.* С.Сабиров // Гомумән кая булса да күтәрелү яки төшү өчен махсус ясалган баскыч яки басма сыман җайланма. *Алтын комлы грунтны тачкага тутырабыз да трап буенча бункерга ашыгабыз. Норма – йөз тачка.* И.Салахов. *Аларның инвалидлар, өлкән яшьтәге кешеләр һәм коляскалы пассажирлар өчен уңайлыклары тагын да арткан: барлык автобуслар да, салонга коляска белән керү өчен, махсус траплар белән җиһазландырылган.* Ватаным Татарстан

3) Самолётка керү яки чыгу өчен сөялмә баскыч. *Траптан күтәрелгәндә дә, иллюминатор аша самолёт канатлары артыннан йөгергән бетон юлга күз салганда да, әллә нинди ят билгесезлеккә тирәнрәк чума баруын тойды.* Э.Закирова. *Ул трапның өске баскычына күтәрелгәч, борылып, аэропорт бинасына карады.* Р.Сәгъди

**ТРАПЕЦИЯ** *и. гр.* 1) Капма-каршы якларның ике ягы гына параллель булган дүртпочмак. *Язын --- Фәридун яшәгән йорт ярыйсы ук нык тоелган иде, хәзер сылавы купкан нигезе, рамнары череп чалшайган кыйшык тәрәзәләре, --- дүрткелдән трапециягә әйләнгән ишек авызы, хуҗасызлыкка корылган һәйкәл булып, аның каршысында сураеп баскан иде.* А.Гыйләҗев.

*Трапециянең нигезләре 12 һәм 18 см икәнлеге билгеле.* Геометрия

2) Һәр ике башы бауга асылган аркылы таяктан гыйбарәт гимнастик снаряд. *[Яшьләрнең] бер төркеме турникларда, трапецияләрдә упражнениеләр ясыйлар, җирдә мәтәклиләр.* Ш.Камал

**ТРА-РА-РАМ** *иярт.* Тынлы оркестрның тантаналы музыка уйнавын яки шундый тантаналы, шатлыклы көй көйләгәндә чыккан тавышны белдерү сүзе. *Бүген әттәм миңа зур туп Бүләк итте – тра-ра-рам!* Җ.Тәрҗеманов

**ТРА́ССА** *и. нем.* 1) Юл, канал, үткәргеч торба һ.б.ш.ларның юнәлешен күрсәтә торган сызык. *Бу яшь урман – калын яшел трасса – Бөтен район кырын ышыклар.* Ш.Мөдәррис. *Метро трассасы. Нефтьүткәргеч трассасы. Трассаны үзгәртү*

2) Олы юл. *Авылның сикәлтәле, кантарлы юлларыннан йөреп туйгач, егет мотоциклны асфальт юлга – трассага таба борды.* Х.Ибраһим. *Ул елларда илдә удар комсомол төзелеше булган КамАЗның гөрләгән чагы, бер үк вакытта Казан–Чаллы трассасы төзелә.* Р.Корбан // Юл, билгеләнгән маршрут. *Туп уйнаганда да, кузла аркылы сикерергә тезелсәләр дә, биеклеккә сикерергә кирәксә дә, чаңгылар кигән килеш трассага чыгып баскач та, иң әүвәл хәлдән тайганчы дөмбәсләшеп алалар.* К.Кәримов

3) *хәрби* Фосфорлы снарядның һавада очканда эзе калып юнәлешне күрсәтә, яңадан атканда прицелны дөресләргә ярдәм итә торган яктырткыч эзе. *Автомат туплар өстеннән Трассалар бөркеми.* С.Баттал. *Очканда эзе күренеп кала торган трасса сызучы пуля белән атканда, пуля хәрәкәтенең траекториясе күренү сәбәпле, цельгә төзәп ату җиңеләя.* Физика

**ТРА́ССАЛАУ** *ф.* Трасса (*1 мәгъ.*) салу, трасса билгеләү. *Трассалау шнуры*

**ТРАТА́ЙКА** *и. рус сөйл.* 1) *к.* **таратайка**. *[Маннур] көпчәкләр урынына ике иске подшипник тәгәрмәче куелган җыйнак кына бер нәмәстәкәй күтәреп, кызлар янына килеп керде. Кызлар: «Ай-һай, кем, Маннур. --- Тратайкаң бик кечкенә түгелме соң?» – [диделәр].* М.Хәсәнов

2) Тоташ тимер торбадан «п» хәрефенә охшатып кәкрәйтелгән ике табанлы чана сыман шугыч (балалар шуның белән шуып уйныйлар)

**ТРАТ-ТА-ТА** *иярт.* 1) Тынлы оркестр тантаналы марш уйнаганда, берәр нәрсәне салмак, ритмик рәвештә шакылдатканда чыккан тавышны һәм шатланганда такмаклауны белдерә. *«Рита калган, Рита биредә, трат-та-та, трат-та-та!» Гамирның шатлыгы йөрәгенә сыешмый, җыр булып тышка атылырга әзер.* Х.Ширмән

2) Автоматтан, пулемёттан атканда чыга торган тавышны белдерә. *Дошман автоматчылары ут ачты: «Трат-та, трат-та-та!»* Ф.Булатов. *Тау башындагы пулемётларның авызы ачылды: «Та... та... та... Трат-та-та-та...»* К.Нәҗми

**ТРАТ-ТАТАМ** *иярт. к.* **трат-та-та** (*1 мәгъ.*). *«Тү-тү-тү, трат-татам, трат-татам», – дип, аякларын танец көенә хәрәкәтләндереп, [Зыя] рояль янына барды.* Ф.Әмирхан

**ТРА́УЛЕР** *и. ингл.* Трал (*1 мәгъ.*) белән җиһазландырылган балык тоту судносы. *Кайчакларда, балык көтүе эзли-эзли, траулер икешәр-өчәр көн диңгездән кайтмый.* Р.Батулла. *Алар тоткан балыкларын якындагы траулерларга илтеп бушаталар да, читкәрәк китеп, ятьмәләрен тагын суга ташлыйлар.* С.Сабиров

**ТРА́УР** *и. нем. кит.* Кеше үлү яки башка төрле зур фаҗига уңае белән кичерелә торган зур кайгы, хәсрәт; матәм. *Гадәттә зур җитәкче вафатыннан соң траур игълан ителсә дә, күпчелек кеше моны үз күңеленә артык якын алмый торган була.* Р.Мөхәммәдиев. *Сталинград катастрофасына Гитлер Германиядә траур игълан итте.* З.Зәйнуллин

**ТРАФАРЕТ** *и. ит.* **1.** 1) Бизәк яки язу төшерү өчен, яссылыгы шул бизәк яки язу формасында уелган юка пластинка. *Эчлек материалларны трафаретлар буенча кисү дә шулай ук меңнәрчә метр материягә экономия бирә.* М.Максуд. *Директорның күз алдында --- кулларына буяу, пумала тоткан сакаллы малайлар кайнашты. – Тизрәк маташ, беренче сылавың түгел бит. – Трафаретлар кайда?* Ф.Баттал

2) Шундый пластинка ярдәмендә төшерелгән рәсем яки язу. *[Солдатның] бил каешлары салдырылган, погоннары һәм трафаретлары йолкынган.* Ш.Маннур

3) *күч.* Шаблон, әзер схема, гадәттәге алым, ысул. *Дистә еллар буена бер трафарет белән куелып килгән классик әсәрләргә баш режиссёр Валерий Васильевич Раку бүгенге заман сулышын өрде.* Р.Вәлиев. *Бүгенге көндә безгә ул «белем» һәм «культура» трафаретларыннан ашыгыч рәвештә котылырга кирәк.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Трафарет ярдәмендә эшләнгән. *Трафарет бизәк*

2) *күч.* Әзер схемага нигезләнгән, еш кабатланганга күрә искергән, таушалып беткән, шаблон белән эшләнгән. *Аларга оригинальлек җитми, гомуми сүзләр, күптән инде күп тапкырлар кабатланган тәгъбирләр, таныш хисләр, трафарет алымнар тулып ята.* Р.Миңнуллин. *Тукта әле, бу нинди трафарет сүз, аяк нишләп төз булсын – бильярд таягы төз була.* З.Мурсиев

**ТРАФАРЕТЛЫК** *и.* Шаблонлык, бертөрлелек. *Рәсми канцелярия стиле өчен рәсмилек, билгеле бер трафаретлык хас.* Фәнни Татарстан. *Образларның трафаретлыгы. Мисалларның трафаретлыгы*

**ТРА́ФИК** *и. ингл. информ.* Телефоннан сөйләшүләр яки Интернет сайтыннан файдалану күләме; компьютер челтәрендә җибәрелгән һәм кабул ителгән мәгълүмат күләме. *Бу кафеда Интернетта утыруның бер сәгате – 20 сум. Иң әзе 15 минутка санатырга була. Интернетның тизлеге шактый зур. Трафик (Интернеттан алган мәгълүматның күләме) буенча түгел, ә вакыт буенча исәплиләр.* А.Әпсәләмова

**ТРАХЕИД** *и. гр. бот.* Үсемлекнең бөтен тармаклары, кәүсәсе, яфраклары буенча су һәм суда эрегән матдәләр таралырга ярдәм итә торган көпшәсыман күзәнәкләр. *Ачыгорлыклыларда үзагач чәчәкле үсемлекләрнекенә караганда*

*гадирәк, ул, башлыча, үткәрү һәм терәк функцияләрен үтәүче калын тышчалы орчыксыман үле күзәнәкләрдән – трахеидлардан тора.* Биология. *Ылыслы агачларда каналлар булмый, алар вазифасын трахеид дип аталган сызынкы ябык күзәнәкләр башкара.* Төзү материаллары

**ТРАХЕИТ** *и. гр. мед.* Трахеяның лайлалы тышчасы ялкынсынудан гыйбарәт авыру. *Мамык, йон, җитен кисәкчекләре сулыш юлларының лайлалы тышчасына ябыша. --- Шулар нәтиҗәсендә профессиональ авырулар – хроник трахеитлар һәм бронхитлар (ялкынсыну процесслары) була.* Анатомия. *Мандарин кабыгыннан ясалган «шулпа» бронхит һәм трахеит вакытында файдаланыла.* Шәһри Казан

**ТРАХЕОТОМИ́Я** *и. гр. мед.* Сулыш юлы тыгылганда, сулауны туктатмас өчен, трахеяга махсус торбачык урнаштыру операциясе. *Тиз арада хирург та килеп җитте. Килүе белән Рөстәмне карады да: «Хәзер үк трахеотомия ясарга кирәк!» – дип, операциягә әзерләнә башлады.* Г.Мөхәммәдова

**ТРАХЕ́Я** *и. гр.* 1) *анат.* Кеше һәм умырткалы хайваннарның бер-берсенә тоташкан кимерчәк боҗралардан торган көпшәсыман сулыш юлы. *Бугаздан үткәч, һава трахеяга керә. Бу – 10–12 см озынлыктагы көпшә.* Анатомия. *Җәүдәт Галиулла улының бугазында рак, трахеясына трубка куелган.* Ф.Бәйрәмова

2) *зоол.* Кайбер буынтыгаяклыларның бер очы тән өстенә чыгып торган сулыш алу көпшәсе. *Үрмәкүчсыманнарның үпкә һәм трахеялары бер-берсеннән бәйсез барлыкка килгән.* Зоология. *Сулышның берничә тибы була: күзәнәк аша, тире аша, трахеялар, саңаклар һәм үпкәләр ярдәмендә. Бу трахеялар буйлап бөҗәк тәненең күзәнәкләренә кислородка бай һава керә.* Биология

3) *биол.* Үсемлекләрдә дымны һәм суда эрегән туклыклы матдәләрне үткәрү көпшәсе

**ТРАХО́МА** *и. гр. мед.* Озакка сузыла торган йогышлы күз авыруы. *Монысының күзләре эренләп тора иде. Шулай да трахомага охшамаган. Конъюнктивит дип тә өзеп кенә әйтә алмассың.* Х.Камалов. *Элегрәк чуашлар арасында медицина ярдәме күбрәк трахомага каршы көрәш юнәлешендә барган.* Сөембикә

**ТРАХО́МАЛЫ** *с.* Трахома белән авырый торган. *[Әхми] канлы, трахомалы күзләрен керле җиңе белән сөртеп алды.* Г.Ибраһимов. *Үземнең трахомалы икәнлекне авылдашларга да, эштә дә белдермәскә тырышам.* Р.Нургали

**ТРАХОМАТОЗ** *с.* Трахоманы өйрәнү, дәвалау белән бәйле

**ТРЕ́БОВАНИЕ** *и. рус* Берәр оешмага яки җитәкчегә нинди дә булса әйбер яки кешеләр сорап язган рәсми кәгазь; таләпнамә. *Лесоскладтан фәлән буй карагай агачына требование язып бирә: себер карагае суда череми икән ич!* Р.Гаязетдин. *Бурычлыларга чакыру кәгазе һәм суд приставы – башкаручыга бару өчен требование тапшырылды.* Мәдәни җомга

**ТРЕВО́ГА** *и. рус хәрби* 1) Куркыныч барлыгын белдереп сигнал бирү. *Фашистларның төнге каравылы безнең разведчиклар хәрәкәтен сизеп ала һәм тревога күтәрә.* Г.Әпсәләмов

2) Шундый сигнал. *Муса белән соңгы тапкыр һава тревогасы вакытында сөйләштем.* Р.Мостафин. *– Кот-ту кайт-та-а-а! – дип сөрән салды кемдер. Бу сугыш башлану тревогасына тиң иде.* А.Хәлим

◊ **Тревога күтәрү** Тавыш чыгару, ыгы-зыгы куптару

**ТРЕД-ЮНИОН** *и. ингл.* Англия һәм кайбер башка илләрдә профсоюзлар атамасы

**ТРЕД-ЮНИОНИЗМ** *и. ингл.* Эшчеләр хәрәкәтенең капитализмга каршы көрәшне икътисади таләпләр белән генә чикли торган агымы

**ТРЕД-ЮНИОНИСТ** *и. ингл.* Тред-юнионизм тарафдары. *Анархист прудонистлар, лассалианистлар, тред-юнионистлар --- кебек төрле агым социалистларының бер оешма эчендә эшләүләре безгә гыйбрәт.* Г.Ибраһимов

**ТРЕД-ЮНИОНИ́СТИК** *с.* Тред-юнионистларга хас. *Тред-юнионистик караш. Тред-юнионистик платформа*

**ТРЕ́ЙЛЕР** *и. ингл.* 1) Авыр йөк ташый торган өсте ачык тәбәнәк платформа-арба. *Күз алдына гына китерегез, иң әүвәл, тамаша башланырга ике атна кала, шәһәрнең уртасына 70 трейлердан торган автокәрван килеп керә.* Шәһри Казан

2) Автомобиль сәяхәтләрендә туктап ял итеп алу, куну өчен көйләнгән тагылма йорт. *Вася әйтүенчә, без аның урманда урнашкан трейлерында бик бәхетле яшәячәкбез.* Саба таңнары

**ТРЕК** *и. ингл.* 1) *спорт* Велосипед һәм мотоцикл ярышларының бер төре өчен махсус ясалган овал формасындагы юл; шундый юлы булган спорт корылмасы. *Бу көнне трекка җитмешкә якын картингчы чыкты.* Ватаным Татарстан. *Биектау районындагы «Каньон» трассасында үткән ял көннәрендә «Империя» кубогына трек ярышлары узды.* Татарстан яшьләре

2) *махс.* Атомнар, электр бушану һ.б.ш.ларның прибор экранында, кәгазьдә калган эзе

3) *муз.* Музыка альбомына кергән аерым әсәр. *Беренче трегыңны кайчан яздырдың?*

**ТРЕЛЬ** *и. ит. махс.* Урманнан агач чыгару өчен махсус салынган юл; шул агач өелә торган урын

**ТРЕЛЬЯЖ** *и. фр.* **1.** 1) Үрмәле үсемлекләр өчен юка, тар такталардан яки тимерчыбыктан махсус эшләнгән рәшәткә

2) Өч бүлемтекле көзге. *Әхмәдиша, галстугын төзәткәли-төзәткәли, трельяждагы чагылышына эре генә карап торды да аяк астындагы ботинкаларына үрелде.* Ф.Баттал. *Клариса, сумкасын трельяж янына куеп, Нуриевның бала-чага кебек бирелеп уйнаганына карап тора.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Юка, тар такталардан эшләнгән. *Трельяж беседка*

**ТРЕНАЖЁР** *и. ингл. спорт* Аерым спорт төрендәге күнекмәләрне яхшырту яки аерым мускулларны ныгыту өчен күнегү ясау җайланмасы. *Чын мәгънәсендә шушы заман егете иде ул, ә андыйлар өстәл артында акча санап кына утырмый, менә дигән тренажёрлары, тәҗрибәле тренерлары булган спорт залларына да йөриләр.* М.Маликова. *Көн саен спортзалда трена-*

*жёрларда шөгыльләндем, татарча көрәш серләренә өйрәндем.* Т.Нәҗмиев

**ТРЕ́НЕР** *и. ингл.* Спорт күнегүләренә җитәкчелек итүче, яшь спортчыларны әзерләүче белгеч. *Кадыйров инде бу атаклы йөгерешчеләрнең серенә төшенә башлаган иде, шуңа күрә моннан таюны хуп күрде. Әмма ул борылырга өлгергәнче, өлкән тренерның боеручан тавышы яңгырады ---.* Ф.Яруллин. *Алҗып егылганнарга да, борынаннан кан китүчеләргә дә эче пошмый бу тренерның.* К.Кәримов

**ТРЕ́НЕРЛЫК** *и.* Тренер булу; тренер хезмәте яки вазифасы. *Бу сумманы яраткан тренерлык эшендә тупларга иде.* М.Ишмәтова. *Билалетдинов, уенчы буларак, Олимпия чемпионы булды, тренерлыкка Юрзинов һәм Моисеев кулы астында өйрәнде.* Ватаным Татарстан

**ТРЕ́НИНГ** *и. ингл.* Нинди дә булса өлкәдә эшләү өчен махсус әзерлек алып бару системасы. *Без, җыелыш җыеп, җитди сөйләшүләр алып бардык, тренинглар, кинодискуссияләр үткәрдек.* Сөембикә. *Яшьләрне кунакчыллыкка өйрәтү, зур аудитория белән эш итү һәм башка серләргә төшендерү өчен, лагерьда төрле өлкә белгечләре тренинглар үткәрәчәк.* Шәһри Казан

**ТРЕНИРО́ВКА** *и. рус* Берәр нәрсәгә (мәс., йөгерергә, йөзәргә, очарга һ.б.га) өйрәнү өчен күнегүләр. *Бүгеннән тренировкаларны башлап җибәрергә иде, ләкин Мөхлисә апа бөтен ишегалдын такта, бүрәнәләр белән тутырган.* Т.Гыйззәт. *Җәмил дә мәктәпкә тренировкага ашыга иде, Сәрвәрбикә әби аркасында гына Вәзилә янында тоткарланды.* А.Гыйләҗев

**ТРЕПАНА́ЦИЯ** *и. фр. мед.* Сөяк астында яки сөяк эчендә булган авыруга операция ясау өчен, сөяккә тишек ясау операциясе. --- *пластик трепанация (баш сөяген ачу) ярдәмендә уң һәм сул ярымшарларны тоташтырган структура аерыла.* Өмет. *Яңа төр операциядә трепанация, ягъни сөяк вату юк.* Кәеф ничек?

**ТРЕПАНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Трепанация ясау, сөякне тишү, ачу. *Зыян күрүченең баш сөяген трепанацияләү*

**ТРЕПАНГ** *и. малай зоол.* Энәтәнлеләр семьялыгыннан ите ашарга яраклы умырткасыз диңгез хайваны. *Трепангларны артык тирән булмаган урыннарда аквалангист-водолазлар тота.* Зоология

**ТРЕСКА** *и. сөйл. к.* **тәрәч**. *Треска күп эләгә иде.* Р.Батулла. *Илнең диңгез яр буйлары төрле балыклар: сельдь, треска, килька һ.б. промыселы урыны.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Д витамины треска һәм палтус бавырында, сельдь, скумбрия, макрель балыкларында, --- атланмайда бар.* Ватаным Татарстан

**ТРЕСТ** *и. ингл.* 1) Үзәкләшкән идарәсе булган бер типтагы берничә предприятие берләшмәсе; шундый берләшмәнең идарә аппараты. *Аны Казандагы төзелеш трестларының берсенә билгеләделәр.* Р.Кәрами. *Шундый җыелышларның берсендә Казаннан тресттан килгән вәкил катнашты.* Ф.Баттал

2) *икът.* Коммерция һәм житештерү операцияләре үзәкләшеп, бер идарәгә буйсынган һәм үз мөстәкыйльлекләрен югалткан берничә предприятиенең монополистик берләшмәсе. *Мексика нефте дә Америка тресты кулына төште.* Ф.Әмирхан

**ТРЕСТЛАШУ** *ф.* Трестка берләшү, трест төзү

**ТРЕФ** *и. яһүд* Уен картасының кара тәре төшерелгән данәсе. *Кәрте, кәрте, нинди уңай төшеп тора, --- Треф сиңа, куркып, күзен терәп тора.* Ә.Фәйзи

**ТРИАС** *и. гр. геол.* Җир шарының геологик тарихында мезозой эрасының иң беренче чоры. *Триас (Мезозой эрасы) ахырында Җир боздан чыга һәм Юра периодында (195 миллион ел элек) Җир йөзендәге түбәнлекләр эрегән сулар белән тула.* География. *Триас чорында беренче имезүчеләр, ә Юра чорында кайбер үзенчәлекләре белән сөйрәлүчеләргә охшаган беренче кошлар яши башлаганнар.* Үсемлекләр дөньясында

**ТРИАЦЕТАТ** *и. лат.* **1.** Ацетат җепселләренең бер төрен ясый торган химик матдә; шундый матдә җепселләре. *Синтетик сүсле тукымалардан (нейлон, капрон, ацетат, триацетат) булган киемнәр сатып алу кирәк түгел.* Безнең йорт

**2.** *с. мәгъ.* Шундый матдә җепселләреннән ясалган, бәйләнгән яки тукылган. *Триацетат ефәк. Триацетат тукыма*

**ТРИБУН** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда: төрле дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында эшләүчеләрнең гомуми исеме

2) Күренекле җәмәгать эшлеклесе – оратор, публицист. *Маяковский рус матбугатында хаклы рәвештә «трибун шагыйрь» дип аталды.* М.Җәлил. *Коеп куйган трибун инде менә...* Р.Мөхәммәдиев

**ТРИБУ́НА** *и. фр.* 1) Оратор басып сөйли торган махсус күтәренке урын; мөнбәр. *Профсоюз әһеле дә сүз алды, инде дә трибуна артына әлеге дә баягы бригадирыбыз Вәлиулла чыкты.* Ф.Баттал. *Шуның өстенә бер-бер артлы трибунага менеп, кем ничек булдыра ала, аны тәнкыйтьләргә тотындылар.* Ф.Садриев

2) Стадионнарда, мәйданнарда төрле уеннарны, ярышларны, демонстрацияләрне карап тору, парад кабул итү һ.б.ш. эшләр өчен, һәр рәте алдагысыннан биегрәк итеп ясалган корылма. *Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: билетны көнчыгыш трибуна бишенче сектордан алырга тырышыгыз.* Сабантуй. *«Рубин» стадионы, традиция буенча, үзебезнең илкүләм җыелмасына трибуна тулы җанатар җыйды.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Сәясәтчеләр, публицистлар һ.б.ш.ның иҗтимагый эшчәнлек алып бара торган өлкәсе, урыны. *Театр сәхнәсе наданлыкны, фикри торгынлык, консерватизмны, яшәп килүче җәмгыятьнең башка тискәре якларын тәнкыйть итү өчен җайлы трибуна иде.* Г.Арсланов. *Укытучы-мөгаллимнәргә укыту методикасы белән, фәннәрнең эчтәлеге һәм терминологиясе буенча тәҗрибә уртаклашырга да трибуна кирәк.* Фән һәм тел

**ТРИБУНАЛ** *и. лат.* 1) Хәрби яки гаять зур гражданлык шикаятьләрен карый торган гадәттән тыш махсус суд органы. – *Һы, ансат кына икән! Анда мине рифкумга тапшырып, трибуналга озаттырасың киләмени? – Ревкомга*

*баруын барырбыз. Тик син трибуналдан курыкма. Трибуналга җибәрмәсләр.* В.Нуруллин. *Хәрби трибунал карары белән хөкем ителгәннәрне дә чокыр кырыена бастырып атканнар.* М.Галиев

2) Шул органның суд коллегиясе, судьялар. *«Әгәр дә, – дигән Һади ага, өстәл артындагы трибунал членнарына карап, – әгәр дә уйдырма гаепләү актыгызда күрсәтелгәнчә, мин контрреволюцион оешма торгызырга, совет хөкүмәтен җимерергә уйлаган булсам, – тагын кабатлыйм, андый ниятнең миндә булганы юк, – кемнәргә, нинди көчләргә таянган булыр идем?»* И.Салахов

3) Шул орган тарафыннан җинаятьләр тикшерү эше. *Маскировка кормаган өчен – трибунал.* Г.Гобәй. *Бу күрсәтмәне җиренә җиткереп үтәмәгән офицерның үзен трибунал көтә.* З.Мәхмүди

4) Шул органның суд утырышы. *Солдатның күз карашы сүнгән, битләре буйлап аккан күз яшьләренең тозлы тәмен сизмичә, иреннәре генә, трибунал, трибунал, дип пышылдый иде...* Х.Ширмән

**ТРИГОНОМЕ́ТРИК** *с.* 1) Тригонометриягә бәйле. *[Рухия] тригонометрик теоремаларның серенә төшенә алмый интегә.* В.Нуруллин. *Башта тригонометрик функцияләр турыпочмаклы өчпочмак якларының үзара нисбәте белән бәйле була.* Геометрия

2) *махс.* Җир өстендәге төп пунктларны билгеләү юлы белән алып барылган геодезик үлчәүләргә бәйле. *Тригонометрик билге. Тригонометрик пункт*

**ТРИГОНОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Геометриянең өчпочмак кырлары һәм почмаклары арасындагы үзара бәйләнешләрне өйрәнә торган бүлеге. *Тик кенә торганда, әйтик, тригонометриядән синуслар, косинусларны үлчәп утырганда, кинәт кенә йөрәк сызлап куя, нindидер сихри көч иясе күңелне күбәләк канатын җилпегәндәй итеп кенә кытыклый: рәхәт тә, газаплы да була.* М.Мәһдиев. *Моңа гаҗәпләнәсе түгел, чөнки Мәккәгә таба юнәлешне тәгаенләү өчен, сферик тригонометрия формулаларын кулланырга кирәк.* А.Тимергалин

**ТРИ́ЕР** *и. фр.* Ашлыкны чистарта һәм сортларга аера торган авыл хуҗалыгы машинасы һәм аның шул эшне башкара торган төп өлеше. *Амбарлар белән тоташ эшләнгән ындыр табагы лапасына килгәч, берьюлы ике триерны көйләп эшләтә башладылар.* Х.Камалов. *Тешен кысып булса да, төне буе триерда иген җилгәрде.* А.Хәлим

**ТРИ́ЕРЛАУ** *ф.* Ашлыкны, чистарту һәм сортларга аеру өчен, триер аша үткәрү

**Триерлап алу** Тиз генә триерлау

**Триерлап бетерү** Барысын да, бар булганын триерлау

**Триерлап карау** Булу-булмавын тикшерү-сынау өчен триерлау

**Триерлап тору** Даими, һәрвакыт триерлау; хәзерге моментта триерлау

**Триерлый башлау** Триерларга тотыну

**ТРИКО** *и. фр.* **1.** 1) Өске кием тегүгә китә торган сырлы йон тукыма. *Минем магазиннарда триколарның да, атласларның да менә дигәннәре тулып ята.* Ш.Камал. *Постау сыман тупас трикодан тегелгән яңа костюм кигән; --- чалбар балакларын, җыеп, оекбашына кыстырган; кулында чемодан, йөзендә ахмакларча елмаю.* Н.Фәттах

2) Шундый материалдан тегелгән кием. *Тротуарларда Англия триколарына киенгән кешеләр йөри.* К.Тинчурин. *Үзләре яшь, матур, байлар. --- Өсләрендә трико да сукно.* М.Фәйзи

3) Трикотаж тукымадан тегелгән һәм тәнгә сыланып тора торган спорт киеме. *Иртән сәгать җидедә тордым, трико киеп, урамга чыктым.* Р.Кәрами. *Ишекне челтәрле ак майка, трико кигән таза гәүдәле бер ир ачты.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Баргач ук һәйбәт трико казаки берлә чалбар тектерәм.* Г.Исхакый. *Тезләре ялтырап чыккан трико ыштан, иңнәре асылынган футболка матур түгел түгелен дә, тик чалбар белән күлмәк бары институтка киярргә генә шул.* Х.Ширмән

**ТРИКОТАЖ** *и. фр.* **1.** 1) Машинада бәйләнгән тукыма. *Ә-ә, әйе, элек трикотаж фабрикасы бухгалтериясендә Лениза белән бергә эшләгән хатын сөйләгән иде.* Х.Камалов. *Күлмәкләр трикотаждан, иркен фасонлы, кулдан бәйләнгән чәчәк элементлары белән бизәлгән.* Т.Ильясова

2) Машинада бәйләнгән әйберләр. *Бары тик озакламый хрусталь, мебель, келәм, палас, көмеш, алтын, күн, --- трикотажның бәясе күтәрелӛчәге хакында яшерен хатлар ала башлагач кына, нидер төшенде кебек.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* Машинада бәйләнгән элеге тукымадан тегелгән. *Кара чалбар, кара трикотаж күлмәк кигән бу кара егет, газапланган бер чырай белән, әллә ничек кенә кызгандырып, микрофон алдына килеп басты.* М.Мәһдиев. *Аягында тәбәнәк үкчәле туфли, өстендә кара трикотаж костюм.* С.Сөләйманова

**ТРИКОТАЖЧЫ** *и.* Трикотаж җитештерү өлкәсендә эшләүче кеше. *Трикотажчылар еллык планны үтәде*

**ТРИ́ЛЛЕР** *и. ингл.* Бөтен интригасы геройга янаган куркынычны көтүгә, билгесезлектән туган психологик киеренкелеккә нигезләнгән әдәби әсәр яки фильмнар жанры. *Хәзер бит нормаль нәфис фильмнар да юк, триллерлар, блокбастерлар гына бар.* Р.Миңнуллин. *Хәер, яшьләрнең дә күбесенә артык уйландырмый торган сюжетлы, төс, тавыш һәм хәрәкәткә бай булган фантастика, триллер жанрындагы фильмнар ошый.* Шәһри Казан

**ТРИЛЛИОН** *сан фр.* **1.** Мең миллиардка бәрабәр сан; шул санның микъдары. *Без күреп торган йолдызларның күбесе триллион ел элек һәлак булган.* Р.Батулла. *Бишенче курс азагында мин әлеге триллион йолдыз – гигант, супергигантлар, кәрләләр, --- шулар тупланган галактикалар, метагалактика арасында үзем эзләгәнне таба алмаячагыма төшенеп җиттем бугай.* Х.Ширмән

**2.** *и. мәгъ.* Бихисап зур акчалар. *Миллиардларны, триллионнарны сез банкларда «әйләндерәсез», үзегез өчен яңа миллиардлар сыгасыз, эшчеләр, игенчеләр исә еллар буе хезмәт хакыннан мәхрүм.* Ф.Баттал

**ТРИЛОБИТ** *и. лат.* Палеозой эрасы башында киң таралган һәм кысласыманнарга охшаган буынтыгаяклы ка-

зылма хайван. *[Ул чорда] киң рәвештә кысла формасындагы трилобит --- таралган булган.* А.Фәткуллин. *Мисс Феллоузны Хоскинс трилобитлар бүлегенә алып килде.* Казан утлары

**ТРИЛО́ГИЯ** *и. гр.* Бер үк автор тарафыннан язылган һәм бер гомуми идея, сюжет сызыгы белән бәйләнгән өч әдәби яки музыкаль әсәр. *Ләкин, зур исәпкә салып уйлансаң, бу язучылар [Факил Әмәк, Фоат Садриев], трилогияләр язуга карамастан, халык өчен зур шәхес булып өлгермәгән әле.* Ф.Яруллин. *Хатынның сессиясе вакытында бер трилогия, ике роман, дүрт повесть --- укып чыктым.* Р.Кәрами

**ТРИМ-ТАМ-ТАМ-ТА** *иярт.* Музыка коралларында уйнаганда, көйләгәндә чыга торган авазларны белдерә яки музыка тактын күрсәтү өчен хезмәт итә торган сүз. *Танца тавышы зал эчендә төн ката. Уйный оркестр: «Трам-там-там-та-та!»* Г.Тукай. *Пыр тузып елый Антанта. Безгә көлке, трам-там-там-та!* Ә.Фәйзи

**ТРИМ-ТА-ТА** *иярт.* **1.** Кәеф күтәрелгәндә, җиңелчә шатлык хисе кичергәндә көйләнә, әйтелә торган авазлар тезмәсе

**2.** *и. мәгъ.* 1) Шатлык хисе кичергәндә сүзсез башкарыла торган көйне аңлата

2) *күч.* Уен-көлке, кәеф-сафа турында гына уйлау; ваемсызлык. *Өсләрендә [аларның] заграничный чүпрәк, башларында бары трим-та-та.* Х.Туфан

3) Җитди булмаган, ваемсыз кеше; җилкуар. *Мин үзем дә дөньяга шулайрак туганмын, үзебезнең братва мине «трим-та-та» дип кенә йөртә.* К.Нәҗми

**ТРИМ-ТРИМ** *иярт.* Кыллы музыка коралларында уйнаганда чыга торган авазлар тезмәсе. *Әй, чәчел, нур, зәррә-зәррә, Яңра, кыллар, трим-трим.* Н.Исәнбәт

**ТРИН-ТРИН** *иярт. к.* **трим-трим**. *Бакча рәшәткәләрен чыбык белән сирпеп үттеләр: «Трин-трин, трин»...* Г.Гобәй

**ТРИ́О** *и. ит. муз.* 1) Өч инструмент яки һәрберсенең мөстәкыйль партияләре булган өч тавыш өчен иҗат ителгән музыкаль әсәр. *Композитор --- дуэтлар, триолар [яза].* М.Җәлил. *«Ярдәм итү» дигән тыйнак сүзләр ышыгында йөзләгән әсәрне эзләп табып, авазларны вакыт юшкыныннан чистартып, трио – виолончель, скрипка, фортепьяно өчен эшкәртеп кую, аннары аны көннәр, айлар дәвамында яздыру --- күздә тотыла.* А.Юнысова

2) Өч башкаручыдан (җырчы яки музыканттан) торган ансамбль. *Акшарлы стенадагы кара кәгазь радио тәлинкәсеннән концерт ишетелә: баянда Кузнецов, Попков, Даниловлардан торган мәшһүр трио уйный иде ---.* М.Мәһдиев. *Хәтеремдә: 60 нчы еллар башында Ильяс баянчылар триосы оештыруда һәм аның өчен репертуар булдыруда күп тырышлык күрсәтте.* М.Макаров

3) Вальс, скерцо һ.б.ш. марш яки бию характерындагы музыкаль әсәрнең төп темага караганда салмаграк, күңелгә ятышлырак урта өлеше

4) *күч.* Гел бергә йөргән яки дус булган кеше

**ТРИОД** *и. гр.* Өч электродлы электрон лампа. *Бу аерма 1906 еллар тирәсендә, Ли Де Форест зәгыйфь радио- һәм аудиосигналларны механик булмаган җайланма ярдәмендә көчәйтергә мөмкин иткән триод уйлап чыгаргannan соң башланган.* Фән һәм тел

**ТРИ́ПТИХ** *и. гр.* 1) *сәнг.* Уртак бер идея, тема белән берләшкән өч картина, өч барельеф һ.б.ш.дан торган композиция. *Аның Третьяков галереясындагы триптихында 1970 еллар ахырындагы техник үзгәрешләрне, индустрияне илаһилаштыру чагыла.* Р.Вәлиев. *«Юллар, юллар...» дип исемләнгән триптихта («Навигация ахыры», «Төнге яшен», «Эш көннәре») хәзерге заманның казанышлары түгел, ә бәлки табигать үзе үзәктә тора.* Мәдәни җомга

2) *әд.* Бер гомуми идея белән берләшкән өч шигырь, өзек һ.б.ш.лардан торган поэтик әсәр. *2012 елның 20 февралендә Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть секциясенә, җәмәгатьчелек фикерен ачыклау өчен, Рүзәл Мөхәммәтшин исемле яшь шагыйрьнең «Ирек мәйданы» дигән триптихы китерелде.* Идел. *Р.Сәлах, әнә, берничә строфалы әсәрен дә триптих дип тамгалап, үзен зур картиналардан шедевр тудырган кебек хис итеп йөри.* Шәһри Казан

**ТРИТОН** *и. гр.* 1) *зоол.* Саламандрачалар семьялыгыннан сырлы сыртлы, озын койрыклы кәлтәсыман җир-су хайваны. *Тритонның озын койрыгы буйлап сузылган зәп-зәңгәр сызыклар ялтырый, аркасы буйлап нәкъ әтәч кикригедәй кикрик тә үскән.* Г.Хәсәнов. *Кайбер вәкилләре, мәсәлән, тритоннар, фәкать сулы тирәлектә генә, башкалары (гөберле бакалар, үлән бакалары) коры җирдә яши.* Биология

2) *астр.* Нептун планетасының ике иярчененең берсе

**ТРИУМВИРАТ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда: республика җимерелер алдыннан, югары хакимиятне кулга төшерү өчен, өч сәяси эшлекле (Цезарь, Помпей, Красс) тарафыннан төзелгән берлек; өчлек бергәлеге. *Властьны үз кулына алу өчен, Цезарьның да, Помпейның да, Крассның да ялгыз гына көчләре җитәрлек булмаган. Алар «триумвират», ягъни «өчлек союзы» дигән яшерен союз төзегәннәр.* Борынгы заманнар тарихы

2) *күч.* Уртак максат, уртак фикер һ.б.ш. белән эш итүче өч кешенең берлеге. *Сезнең янда Пушкин, Лермонтов, Некрасовлар рухи һавасы яшәгән, Чернышевский, Белинский, Добролюбовлар триумвиратының тере фикерләре Сезнең киңәшчеләрегез булган ---.* Х.Туфан. *Авылда триумвират «идарә итәргә» тиеш: авыл җирлеге башлыгы, хуҗалык җитәкчесе, полициянең участок уполномоченные.* Кәеф ничек?

**ТРИУМФ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда сугыштан зур җиңү белән кайтучы сәргаскәрнең һәм аның гаскәренең, ганимәтләрен күрсәтеп, шәһәр аша Юпитер Капитолийский гыйбадәтханәсенә таба узу һәм аларны каршы алу тантанасы. *Цезарьның триумфы*

2) *кит.* Гаять зур җиңү, зур уңыш; зафәр, тантана. *Бу триумф иде, бу олы зафәр, зур җиңү иде; бу еллар буе түккән тиргә, еллар буе түккән нервларга түләү иде.* Р.Батулла. *Әле күптән түгел генә Мәскәүдән триумф белән кайткан драматургларның*

*үзләре әйтүләренә караганда, Мәскәү тәнкыйтьчеләре дә, татар балалар драматургиясе юк, дигән карарга килгәннәр ---.* Р.Миңнуллин

**ТРИУМФАЛЬ** *с.* 1) Җиңүченең триумфына бәйле, шуңа караган. *Триумфаль киемнәр*

2) Нинди дә булса җиңү, тантана хөрмәтенә корылган. *Триумфаль арка алдына канал аркылы кызыл тасма сузылган.* Ш.Мөдәррис. *Кара халык өчен сарай янында һәм шәһәрдәге барлык триумфаль капкалар тирәсендә исерткеч тутырган мичкәләр һәм кабымлыклар куела.* Татарстан яшьләре

3) Тантаналы, җиңүле. *[Фидаи] һәрвакыт дулкынлана, ялкынлап яна һәм романтик ашкыну белән революциянең триумфаль адымын сурәтләргә омтыла.* Г.Кашшаф. *Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале бөтен татар дөньясы буйлап триумфаль төстә атлавын дәвам итә.* Татарстан яшьләре

**ТРИУМФА́ТОР** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда тантаналы рәвештә каршы алуга, триумфка лаек җиңүче сәргаскәр. *Лукуллдан соң Помпей басып керә. Триумфатор көтә Рим – Сенат.* Н.Арсланов. *Триумфатор атлары*

2) Зур җиңүләргә ирешкән зат. *Шорт-тректа Турин Олимпиадасының абсолют триумфаторы булган Көньяк Корея җыелма командасына өч алтын һәм бер бронза медальне Ан Хён Су китерде ул чакта.* Ватаным Татарстан. *Комитет шулай ук Универсиада триумфаторы чаңгычы Алия Иксанова өчен өстәмә – бишенче премияне бүлү турында Хөкүмәткә үтенеч юллады.* Татарстан яшьләре

**ТРИХИ́НА** *и. гр. зоол.* Личинкалары дуңгыз яки башка хайван итләрендә була һәм итле ашамлык ашаган кешегә күчә торган чәчсыман нечкә паразит суалчан. *Аның итендә булган трихина дигән паразит без ашаган ризык белән ашказаныбызга, шуннан каныбыз белән бөтен тәнебезгә тарала.* Кәеф ничек?

**ТРИХИНЕ́ЛЛА** *и. лат. зоол. к.* **трихина**. *Кешедә паразитлык итүче башка йомры суалчаннар арасында нечкә һәм юан эчәкләрдә яшәүче бабасырны, эчәклектә яки мускулларда урнашучы трихинелланы, тән калынаю авыруына китерүче җеп суалчан, яки филлярияне һ.б.ны әйтергә була.* Биология. *Моны медицина да инкяр итми: эчәклектә вак тасма суалчан, тиредә дуңгыз чуаны, мускуллар арасында трихинелла дигән хәшәрәт һәм башка төрле авырулар дуңгыздан күчә икән.* Шәһри Казан

**ТРИХИНЕЛЛЁЗ** *и. лат. махс.* Кешедә яки хайваннарда трихина тудырган авыру

**ТРОЕБО́РЬЕ** *и. рус* Спортның өч төре буенча яки бер спорт төренең өч көнегүеннән торган ярыш; өч төр ярыш. *--- Анастасия ярышларның троеборье төрендә: урыннан сикерүдә – I, 100 метрга йөгерүдә – II һәм шәхси зачётта – III урынга чыкты.* Татарстан яшьләре

**ТРО́ЙКА** *и. рус* **1.** 1) Бер арбага яки чанага янәшә җигелгән өч ат; өч аттан торган җигем. *Моны тройкага тимер арба җигеп барып алалар.* Әкият. *Әмма Әбүзәр абзый шуннан соң бүтән беркайчан да тройкага утырмый.* Г.Әпсәләмов

2) Өч ат җигелгән арба яки чана. *Ул тройкага сикереп менде дә --- чаптырып шәһәргә китте.* Г.Тукай. *Габдрахман хәзрәтнең ике остабикә белән --- тройкада кунакка йөргән күреп, [Җиһаншаның] фикере үзгәрде.* З.Һади

3) *сөйл.* Берәр махсус эш өчен өч кешедән торган вакытлы орган яки комиссия; өчлек. *Әмма анда аны, дезертир дип, тройка кулга ала.* А.Хәсәнов. *Халык дошманнарын бертөрле дә закон кысаларына сыймый торган тройка үлем җәзасына хөкем итә.* М.Әхмәтҗанов

4) Пиджак, чалбар (яки итәк) һәм жилеттан торган костюм. *Ниһаять, егет хәзрәтне ваннага алып китте һәм, аннан чыгуга, киң генә тегелгән тройка (пиджак, брюка, жилет) тәкъдим итте.* Ф.Әмирхан. *Өстенә Петербург мастерларыннан махсус тектергән иң яхшы тройкасын кияр иде ---!* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* 1) Өчәү бергә җигелгән. *Көненә ун тәңкә генә булса да, --- тройка атлар алырга була.* Г.Камал. *Бердән, исемең була депутат, җиккәнең була тройка ат.* Ш.Мөхәммәдев

2) Пиджак, чалбар (яки итәк) һәм жилеттан торган. *Өстенә кара материядән тройка костюм, башына кара бәрхет кәләпүш кигән, муенына көрән галстук таккан кеше керде.* И.Нуруллин

**ТРО́ЙКАЛЫ** *с.* Өч ат җигелгән арбалы яки чаналы. *Троицкида вәгъдә куешкан тройкалы ике немец вояжёры безне урманда туктап көтәләр икән.* Г.Тукай. *Миңа басу капкасы төбендә озак көтәргә туры килмәде, теге тройкалы повозкалар артыннан озакламыйча кайтып җитүчеләр голова Хәйбулланың --- яхшы, таза контор --- атларына утырып кайтучы әтиләр булды.* Г.Камал

**ТРОЙНИК** *и. рус махс.* 1) Нинди дә булса сыеклыкны өч юнәлештә агызу өчен, «т» хәрефенә охшатып, өч япьле итеп ясалган, торбалар тоташкан урында куела торган махсус деталь. *[Монда] клапаннар, тройниклар бар иде.* М.Шәрифуллин

2) Электр челтәренә берьюлы өч прибор ялгарга мөмкинлек бирә торган җайланма. *Розеткага тройник тыгып, берьюлы берничә прибор тоташтырмагыз.* Безнең йорт

**ТРОЛЛЕ́ЙБУС** *и. ингл.* Электр тогы ярдәмендә хәрәкәтләнә торган күбурынлы пассажир транспортының бер төре. *Мәскәүдә тагын бернәрсәгә игътибар итте Фәләх: метрода китап укыйлар, троллейбуста укыйлар ---.* В.Нуруллин. *Алар башта трамвайда, аннары троллейбуста бардылар.* М.Маликова

**ТРОМБ** I *и. гр. мед.* Кан тамырларын томалый торган оешкан кан яки башка матдә төере. *Аның селәгәендә герудин дигән аксым бар, ул кан тамырларында канның оюын һәм тромблар ясалуын (һәм зураюын) тоткарлый.* Биология. *Кызыл сугандагы аллицин дигән матдә исә тромблар барлыкка килүне кисәтә, кан тамырлары тышчасының сыгылмалылыгын тәэмин итә.* Шәһри Казан

**ТРОМБ** II *и. фр.* Коры җирдә була торган, бер очы яңгыр болытына то-

ташкан каралҗым баганага охшаш көчле өермә

**ТРОМБОЗ** *и. гр. мед.* Кан тамырларында кан оешу процессы. *Томат согын даими куллану кан юлларында тромбоз авыруы барлыкка килүдән саклый.* Ватаным Татарстан. *Кисәк кенә башланган авыруның сәбәбе аяктагы кан тамырлары тыгылу – тромбоз икәнлеге ачыклана.* Татарстан яшьләре

**ТРОМБОН** *и. ит.* Торбаның бер буынын шудырып йөртүдән яки клапаннарга басудан тавыш югарылыгы үзгәрә торган, түбән тавышлы тынлы музыка коралы. *Тромбон, күпсанлы быргылар туып килгән иртәне сәламлиләр.* А.Хәсәнов. *Аннан соң кларнетта, флейтада, тромбонда уйнарга өйрәндем.* Р.Вәлиев

**ТРОМБОНЧЫ** *и.* Тромбонда уйнаучы музыкант. *Тромбончы Артур Гыйльфанов та музыка сәнгате күгендә югары күтәрелде: Д.Орлов җитәкчелегендәге Мәскәү дәүләт симфоник оркестры составында уйнап, ничәмәничә илләрне гизде, дөнья күрде.* Хезмәт даны

**ТРОМБОФЛЕБИТ** *и. гр. мед.* Кан оешып, кан тамырлары каплану сәбәпле, аларның ялкынсынуы. *Профессор үзе карады. Сезнең аякларыгызга электрик ванналар кирәк, ди. Югыйсә тромбофлебит булуы ихтимал, ди.* Ә.Фәйзи. *Диңгез кәбестәсе йөрәк эшчәнлеген яхшырта, --- ашказаны асты бизе авырулары һәм тромбофлебит вакытында ярдәмгә килә.* Мәдәни җомга

**ТРОП** *и. гр. әд.* Күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүз яки әйтелмә. *Троп – сөйләмнең сәнгатьлелеген, образлылыгын арттыру максатыннан күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләр яисә сүзтезмәләр.* Г.Галиуллина. *Шигърияттә традицион символларның трансформацияләнүе, яңа эчтәлеккә ия күптөрле троплар барлыкка килү дә нәкъ менә бер гасыр элек күзәтелә.* Р.Харрасова

**ТРО́ПИК** I *и. гр.* 1) Җир шарында экваторга параллель һәм аннан төньякка яки көньякка таба 23°27’ка урнашкан ике киңлекнең берсе. *Күзләремне ачмый гына юрганга төренеп яттым да, бүген төнлә Кысла тропигын үтеп, тропикларга кирәргә тиешлегебезне искә төшердем.* Р.Мостафин. *Кәҗәмөгез тропигы дигән термин шушы йолдызлык исеменә бәйле.* А.Тимергалин

2) Шул киңлекләр арасы

**ТРО́ПИК** II *с.* 1) Тропик I киңлекләрендә урнашкан, шунда үсә торган. *Ялан аякларны корт чаккан кебек чәнчеп ала торган шайтан таяклары да андый ук ямьсез булмаган икән: тропик үсемлек сыман купшы булып утыра.* М.Галиев. *Җәннәт булгач, анда куе тропик урманнар, фил, крокодил һәм зур-зур еланнар яши торган джунгли да булырга тиештер.* Р.Мөхәммәдиев

2) Тропиклар өчен хас, тропик поясларда очрый торган. *Китәсе көнне Цейлон утравы безгә тропик яңгырын күрсәтте.* М.Мәһдиев. *Кытайның Гонконг районнарына тропик шторм, ягъни җилле-давыллы яңгыр якынлаша икән.* Татарстан яшьләре. *Тропик авырулар. Тропик бөркүлек*

3) *астр.* Кояшның язгы көн-төн тигезлеге аша ике мәртәбә үтү арасына тигез булган. *Григорий календаренда 4 ел арасында елның уртача дәвамлыгы 365,2425 тәүлек, бу исә иске стильдәге тропик елдан 26 секундка гына артык.* Фән һәм тел

**ТРОПОСФЕ́РА** *и. гр.* Җир атмосферасының стратосферадан түбәнрәк урнашкан катламы. *Атмосфераның иң аскы катлавында, без тереклек итә торган тропосферада, тормыш өчен бик кирәк булган су әйләнеше бара ---.* Физика. *Тереклек өчен, шулай ук Җирдә бара торган процесслар өчен, атмосфераның түбәнге катлавы – тропосфера – иң зур әһәмияткә ия ---.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТРОС** *и. голл. махс.* **1.** Диаметры 25 мм дан 102 мм га кадәр юанлыкта ишелгән сыгылмалы корыч яки сүс аркан. *Күрәм: --- троллейбус сыртындагы тәртәсе ычкынып туктап калды. Ут очкыннары чәчрәде, баганаларны аударырдай булып, трослар тартылды.* Р.Кәрами. *Сал өстендәге теге ират, --- ишелергә дип ашкынган бүрәнәләргә ирек бирмичә, берүзе тросны тартып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый арканнан ясалган, шуннан гыйбарәт. *Трос баскыч*

**ТРОТИЛ** *и. ингл. махс.* Шартлаткыч матдәләр ясаганда, шартлату эшләрендә аерым һәм катнашма рәвешендә кулланыла торган саргылт төсле кристалл рәвешендәге шартлаучан матдә. *Биш килограммнан артык тротил тагып, үлем кочагына үз теләге белән кергән хатын куенындагы сабый исән калмас иде барыбер.* Шәһри Казан. *Бинадагы кабинетлардан берничә төр калибрлы пистолет һәм мылтык патроннары, шартлаткычлар, электродетонаторлар, тротил шашкалар табылган.* Татарстан яшьләре

**ТРОТУАР** *и. фр.* Җәяүле кешеләр йөрер өчен, урамның ике ягында бераз күтәртебрәк салынган асфальт, таш яки такта юл. *Ул, баш яулыгының күз яшенә чыланган бер почмагы белән йөзен каплап тротуар кырыена утырган да, тирән уйга баткан иде.* М.Галәү. *Аяк тавышына башын калкытса, каршы тротуарда бер күләгә күрә.* И.Гази

**ТРОФЕЙ** *и. гр.* **1.** 1) Сугыш вакытында каршы яктан яулап алынган корал яки хәрби кирәк-яраклар, әйберләр; ганимәт, улҗа. *Аксак Тимер дә күп кешесен югалта, шуңа күрә, сугыш кырында җиңүгә ирешсә дә, Сарайга барып җитми, көнбатышка яу чапмый, хәтсез трофей кулга төшереп --- Сәмәркандына кайтып китә.* Р.Фәхретдинов. *Сугыштан кайтучыларның трофейлары – сәгатьләр, уйный алмасалар да аккордеоннар, башка затлы әйберләр – таламыйча гына алынганына ышанасыңмы?* Ш.Алпар

2) Берәр җиңүне, уңышны, батырлыкны хәтерләтә торган истәлек әйбер. *Балыкчы трофее белән мактана*

**2.** *с. мәгъ.* Сугышта яулап алынган, яки җиңелгән яктан калган. *Каяндыр бишекле трофей мотоцикл да кулга төшергән, кирәк җиргә шуның белән генә чаба.* Х.Камалов. *Зәкәриянең фронт капчыгында һәрвакыт көмеш көпшәле трофей револьвер йөрде.* Г.Гыйльманов

**ТРО́ФИК** *с.* 1) *физиол.* Тән тукымаларын яки әгъзаларны тукландыруга, матдәләр алмашынуга бәйле. *Һәр*

*органга трофик нервлар кылә, алар, югарыда әйткәнебезчә, органда матдәләр алмашуның химик процессын регуляцияләләр.* Совет әдәбияты

2) *мед.* Туклану, матдәләр алмашы бозылу белән бәйле. *Гади генә бетчә, тик торганда, бөтәү ярага (трофик язвага) әверелә.* З.Мәхмүди. *Трофик җәрәхәтләр, чиләнә торган экзема һәм рожа өстенә стериль марляны әрекмән төнәтмәсенә чылатып куялар.* Сәламәт булыйк!

**ТРОЦКИЗМ** *и. рус тар.* Л.Д. Троцкий карашларына нигезләнгән сәяси агым. *Троцкизмга каршы ызгышларда мин иң көчле оратор булдым.* Р.Батулла. *Гомәр Гали 1937дә советларга каршы юнәлтелгән милләтчелектә һәм троцкизмда гаепләнеп кулга алына.* Гасырлар авазы

**ТРО́ЦКИЙЧЫ** *и.* Троцкизм тарафдары. *1937 елда Г.Ибраһимовны «Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә катнашуда гаепләп кулга алалар.* Фән һәм тел. *Гаепләнүче Гыйльми Шакиров совет властена дошманнарча карап, янәсе, элекле рәвештә контрреволюцион, советка, колхозга каршы, троцкийчыларны яклап, агитация алып барган.* Гасырлар авазы

**ТРР** *ы.* Атны туктатканда әйтелә. *Ат тыпырчынды, башын селеккәләде. – Трр, дим, анаңны корт чаккыры! Чү, дим, чү.* М.Мәһдиев. *Әтинең трр дип ат туктаткан тавышына уянып киттем бу юлы.* Р.Мөхәммәдиев

**ТРУБА** *и. рус к.* **торба**. *Михач элек койрыкта баручыга, аннан нечкә труба аркылы түбәндәгеләргә кычкырды.* К.Нәҗми. --- *кайдадыр трибуна артында оркестрантларның әллә нидә бер трубаларын кычкыртып куйганнары гына ишетелгәләп куя иде.* Ф.Хөсни

**ТРУБАДУР** *и. фр.* 1) *тар. сәнг.* Урта гасырларда Көньяк Франциядә илгизәр шагыйрь. *Европада Урта гасырның трубадур дип аталган һөнәрмәнд җырчылары йөргән.* Г.Сәгъди. *Җырчы-композитор, искечәрәк әйтсәк, трубадурлар, поэты-песенники дип бүгенчә әйтсәк, бу мода да безнең халыкта әллә кай заманнардан булган.* Р.Батулла

2) *күч.* Берәр нәрсәне бик нык мактап, аңа дан җырлаучы кеше. *Искелекне җимерү көрәшенең трубадурлары булу гына түгел, ә яңаны, социализмны төзүчеләрнең алгы сафына басып тору идеалы күпләгән шагыйрьләрнең аңын һәм хисен үзенә тартты.* Г.Халит

**ТРУБА́КИСКЕЧ** *и. тех. к.* **торбакискеч**

**ТРУБА́Ч** *и. рус к.* **трубачы**. *Музыкантлардан трубач Байсаров сигнал уйный.* Ш.Маннур. *Безнең баракта Кириленко фамилияле бер трубач яши. Начальство аны лагерь оркестры составына кертте.* Совет әдәбияты

**ТРУБА́ЧЫ** *и. к.* **торбачы**. *Үзенең гражданлык бурычын аңлаган, үгетләүгә тиз бирелә торган Сәйдәш Беренче татар укчы бригадасына трубачы һәм капельмейстер булып китәргә ризалык бирде.* Р.Низамиев. *Филармония сәхнәсендә Франция трубачысы Жан-Луи Лоньон, Куба җырчысы Ивонн Санчес --- кебек музыкантлар чыгыш ясаячак.* Кызыл таң

**ТРУ́БКА** *и. рус* 1) Телефон аппаратының сөйләү һәм тыңлау өчен махсус җайланмасы. *Тикшерүче телефон трубкасын күтәреп чылтыратты.* В.Юныс. *Хәлимә ападыр дип уйлап барган иде, телефон трубкасында Сөембикәнең тавышын ишетеп, гаҗәпсенеп куйды.* Ф.Садриев

2) *к.* **төрепкә**. *Икесе кызыл балчыктан ясалган трубка чыгарып тәмәке көйрәтә башлады.* З.Зәйнуллин. *Хуҗам трубкасы белән тәмәке янчыгын һәрчак урман авызында, берәр агач төбенә яшереп киткән була.* М.Галиев

3) Берәр әсбапның цилиндр, көпшә формасындагы торбачыгы. *Бөтен җиреннән трубка чыгып торган бәбиен күргәч, ул елап җибәрә.* Сөембикә. *Борһан абый, колагына эрзин трубка куеп, сыерыбызның күкрәген, эчен тыңлап тикшерде ---.* Мирас. *Хастаханәдән Лилия яхшы хәлдә чыкмый: трубка аша сулый, ашый.* Шәһри Казан

**ТРУ́БКАЧЫ** *и. сөйл.* Трубка (*2 мәгъ.*) тартырга яратучы кеше. *Картларның аерата суфи бер төркеме, авылда бердәнбер трубкачы Гаптрахман абзый бакчасына кереп, тәмәке дип кыяр кәлшәсен утап чыккан.* Ш.Маннур

**ТРУБОПРОВОД** *и. рус тех.* Сыек яки газсыман матдәләрне ерак арага күчерү, агызу өчен хезмәт итә торган һәм махсус техник җайланмалар белән җиһазландырылган тоташ трубалар системасы. *Трубопроводларның эстакадасы никадәр якынлашкан.* Г.Әпсәләмов. *Машинаның тормоз системасына су эләгеп туңган, һәм ул урыныннан кузгалмый. Җылыткыч лампа белән тормоз клапаннарына һава бирә торган трубопроводларны җылыта-җылыта, су туңган җирне эзлибез.* З.Зәйнуллин

**ТРУДОВИК** *и. рус тар.* Октябрь инкыйлабына кадәрге Россия Дәүләт думасында народниклык юнәлешендәге вак буржуаз демократик партия әгъзасы. *Киләчәк заман депутатларыбыз да «сукыр трудовик» булып йөрмәсләр.* Г.Тукай. *Без трудовик социалистлардан мондый сүз ишетелүенә бик гаҗәпләнәбез.* Урал

**ТРУ́ППА** *и. нем.* Бер театрның, циркның артистлары коллективы. *Ул дәвердә татар театр труппаларының төп составын, көчен сәхнәгә ихлас бирелгән һәвәскәрләр тәшкил итә.* Д.Гыймранова. *Быелгы «Нәүрүз» театр фестиваленә Германия, --- Молдова һәм Русиянең Якутия, --- Хакасия кебек өлкәләреннән театр труппалары --- киләчәк дип көтелә.* Р.Сәгъди

**ТРУ́СИК** *и. рус* Эчке кием буларак киелә торган юка материядән тегелгән балаксыз ыштан. *Фингал трусик белән майкадан, бите-муены кызыл таплар белән чуарланган.* М.Маликова. *Кинәт --- экранда скелеттай бәндә пәйда булды. Киң трусигыннан таяктай нечкә камыт аяклары сузылып төшкән, --- куллары кәкре җәмки шикелле.* Ф.Баттал

**ТРЮК** *и. фр.* 1) Циркта һәм эстрадада оста, эффектлы катлаулы алым; оста, кискен хәрәкәт. *Рәфкать Бикчәнтәйнең спектакльләре үзе кебек җиңел, трюкларга, көлке ситуацияләргә бай, якты, матур килеп чыга иде.* Р.Батулла. *Фокусчы, бер трюкны башкарганда, катлаулы булмаган, гади генә хәрәкәтләр ясый сымак.* Р.Гарифуллин

2) *куч.* Хәйләгә корылган һәм оста итеп башкарылган эш; көтелмәгәндә (гадәттә, кемне дә булса алдау максаты белән) эшләнгән гамәл. *[Тикшерүче] бу трюк белән Баймурзиннарның мөнәсәбәтен ачыклый алмады.* С.Баттал. *Мондый реклама трюклары һәм пропаганда акцияләре өчен тотылган миллиардлар, шиксез, халык массаларыннан савылган триллионнар булып кире әйләнеп кайта.* Татарстан яшьләре

**ТРЮКЧЫ** *и. сөйл.* Трюклар ясаучы кеше. *Мин [циркта] трюкчыларны карарга бик яратам.* Н.Исәнбәт

**ТРЮМ** *и. голл.* 1) Корабльнең түбәндәге палубасы белән төбе арасындагы йөк тутыру яки башка хаҗәтләр өчен файдаланыла торган бушлык. *Безне ниндидер бер иске, кара майга буялып беткән баржаның трюмына төшерделәр.* М.Юныс. *Пароход трюмында гына аңына килде ул.* М.Галиев

2) *театр* Сәхнә астындагы урын

**ТРЮМО** *и. фр.* 1) Гадәттә ике тәрәзә арасына идәнгә бастырып яки стенага беркетеп куела торган зур биек көзге. *Сибгатулла, бераз мактангандай, трюмоларга, шифоньерларга төртеп күрсәтте.* Ф.Яруллин. *Трюмо каршында чәчен рәтләп тора иде, ишектән атылып Гөлсәрия килеп керде.* Н.Көбәш. *Һәдия яңа алган трюмоны барып карарга булды.* Д.Каюмова

2) *махс.* Төрле орнаментлар белән бизәкләнгән тәрәзә арасы

**ТРЮ́ФЕЛЬ** *и. нем.* 1) *бот. к.* **томалан**. *Балыктан соң француз нәмәрсәләре китте: дерелдәвек сыман нәрсә, ә эчендә үлән-мазар, ит кисәкләре һәм трюфель гөмбәсе сыныклары – җыен юк-бар.* М.Хәмзина. *Дөньяда иң кыйммәтле гөмбә – трюфель.* Татарстан яшьләре

2) Шул гөмбә формасында ясалган шоколад конфет исеме. *Конфетлар трюфель массасы нигезендә әзерләнәчәк. Бүләккә трюфель сатып алырга булдым*

**ТС** *ы.* Сөйләшмәскә, тик торырга өндәгән сүз; чү, дәшмә, шыпырт, тч. *Тс-с. Операция ясыйлар.* А.Гыйләҗев. *Тс-с-с, кычкырып сөйләшмә.* З.Хәким. *Артта утырганы, тсс дип, пистолет көпшәсен иреннәренә куйды.* Т.Галиуллин

**ТУ** I *и. бор.* 1) Төрки һәм монгол халыкларында бер башы очланган яисә шар куелган, кырыйларына ат койрыклары асылган һәм уртасына ай сыны ябыштырылган штандарт. *Карагай башы ку булыр, Хан билгесе ту булыр.* Әйтем. *Һәм, мөкатдәс көрәш туын биек җиргә кадап, Сөйләр идем бер нотык, Алдымдагы илгә карап.* К.Нәҗми

2) Бер хәрби җитәкче кул астына җыелган гаскәри берәмлек

3) Аучының кошлар кундыра торган агачы. *Тугрысы юк шоңкармын, Ту җәбендә очармын.* Дастан

◊ **Ту киңәш** *тар.* Сугышта катнашучы аерым ыру, кабилә һ.б.ш.ларның гаскәр башлыклары киңәше; хәрби совет. *Дүртәү-бишәү бер булып, Әүвәлгедәй безнекеләр Ту киңәшкә килсә иде!* Дастан. **Ту күтәрү** *этн.* Бүләкләр бәйләнгән сөлгеле таяк күтәреп, Сабан туе ярышлары башлануын хәбәр итү

**ТУ** II *с. диал.* 1) Бик озак вакыт җигелми яки савылмый йөргән симез (хайван тур.). *Ту бияләр суйдырды, Утыз көн уен кылдырды, Кырык көн туен кылдырды.* Дастан. *Дөньяныкы дөньяда бетсен: Азым әкәне җибәреп үтенечемне әйтим, килсә ту бия суйдырып, кымызны мул куеп, асыл елкыдан үзенә бернича кара бүләк биреп, ризалыгын сорыйм.* Г.Ибраһимов. *Идегәй Акбеләкне коткарып алып кайтканнан соң да, Шаһ Тимер ту бияләр суйдырып туй ясый.* Гасырлар авазы

2) Кысыр. *[Бу] кайчандыр сөрелгәнчәчелгән җир булып та, күп еллар сука-сабан тимәү аркасында яңадан чирәмгә әйләнгән ту җир иде.* М.Әмир. *Ту каз. Ту үрдәк. Ту сарык*

**ТУАЙ** *ы.* Колынны, атны яки сыерны, бозауны чакыру сүзе. – *Туай, туай, туу... сана! Туктап кына торсана! Килче, ялың тараем.* Н.Исәнбәт

**ТУАК** *с. диал.* Яңа гына туган. *Вак кына, туак кына, Бәләкәй генә, куак кына.* Такмак

**ТУАЛЕТ** *и. фр.* 1) Киемнең тулы комплекты (гадәттә, хатын-кызларныкы). *Кичке туалет*

2) Юыну, бизәнү, чәч тарау, киенү һ.б.ш. эшләр. *Латиф иртәнге туалетын башкарып, гантельләр белән физзарядка ясый.* А.Расих. *Аңардан, икенче юлы килгәндә, үземә кирәкле булган тарак, теш щёткасы, паста, сабын кебек туалет әйберләре алып килүен сорап, язу ыргыттым.* Ш.Алпар

3) Бәдрәф бүлмәсе. *Армиягә баргач, беренче көнне үк бер «дед» дигән шәһәр малае бәйләнеп караган икән: туалетка барасым килә, мине атландырып алып бар әле, дип.* М.Мәһдиев. *Туалетка кереп, юынгычка борылуга, каршыдагы көзгегә күзе төште, һәм ул бер мәлгә өнсез калды: аның чәчләре яртылаш агарган иде!* Ф.Садриев

**ТУАЛЕТЛЫ** *с.* Туалеты (*1, 3 мәгъ.*) булган. *Түрәләр ванналы, туалетлы люксларда түш киереп йөри, гади кеше саф һава суларга зарыгып ята.* Ф.Яруллин

**ТУАР** *и.* Йорт хайваннары, терлек, мал. *Туар булса – тун булыр, бодай булса – он булыр.* Мәкаль. *Сыер юк. Сарык-кәҗә дә кош-корт. Аннары менә кроликлар асрыйм. Шул вак туар белән дә иткә-майга аптыраган юк минем.* Р.Төхфәтуллин. *Сөт туары. Туар асрау*

**ТУА́Р-КАРА** *җый. и. диал. к.* **малтуар**. *Аларның ат-тун, туар-кара хакында кайгы беткән.* Ак юл

**ТУАРУ** *ф.* 1) Җигелгән атны яки башка хайванны чана, арба һәм башка җигү дирбияләреннән азат итү. *Егетләр, ниһаять, Бәдретдиннең авылына килеп җитә, атларын туара.* Ә.Еники. *--- кодалар ат туарган арада, ул кызыннан бер кадак май белән ярты каз сорап алган да, лапас астына кереп, шуларны сыпыртып чыккан.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Нинди дә булса эшкә дәрттеләкне киметү, сүлпәнләтү. *Без әзерләнәбез, кешеләрне әзерлибез. --- Ә [атыш] юк. Бу нәрсә халыкны бераз туара, сүлпәнләтә башлый.* Х.Мөҗәй

**Туара башлау** Туарырга тотыну. *Җәмилнең әткәсе арбаны бер җайлы урынга китереп туктатты да Җирәнкәйне туара башлады.* Н.Фәттах. *Мисбахетдин атларын туара башлады.* Г.Әпсәләмов

**Туарып бетерү** Тулысынча туару. *Туарып бетергәч, атны, тезгеннән тотып, бер читкә алып барды һәм әкрен*

*генә сызгырырга тотынды.* Г.Әпсәләмов. *Әткәсе атны туарып бетергән иде.* Н.Фәттах

**Туарып карау** Бу эшне булдыра алу-алмавын тикшерү-сынау өчен туару

**Туарып кую** Алдан яки тиз генә туарылган хәлгә китерү. *Бүре суккан энекәш атын туарып куйды да --- ашыгып китеп барды.* Г.Якупова. *«Мәле, атны туарып куй», – дип, дилбегәсен генә тоттырды да клубка тәпиләде.* Ә.Дусайлы

**Туарып ташлау** Тиз генә, тиз арада туару

**ТУАРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **туару**. *Анда койма күләгәсенә кертеп туарылган һәм керт-керт печән ашап торган ат, аның янында зур гына тарантас.* Ә.Фәйзи. *Өй каршында туарылган аты арбасына салынган үләнне ашый.* Р.Сәгъди

2) *күч.* Чишенү. *Ә син, сакал, нәрсә дип туарылдың? Ки итекләреңне!* К.Нәҗми. *Тәмам чишенеп, туарылып ташлаган да Рөстәм, диванга чалкан ятып, китап укый.* Л.Ихсанова

3) *күч.* Физик һәм рухи киеренкелектән бушану. *Йөзем, кызларга хас булганча, бик ачылып китмәде, үзенең күңелен тыйнак кына, сабыр гына чиште, Булат исә бөтенләй туарылды: мәхәббәт сүзләрен сипте генә!* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Гадәти норманы бозу, үз-үзен начар, артык иркен тоту, тәртипсезләнү. *Яшьләрнең болай туарылып китүе аны Яңгураның тузынуыннан бигрәк куркытты.* Г.Әпсәләмов. *Хәлил исә, ул чыгып киткәч, чын-чынлап туарылды: – Кара син аны, кәнтәйне, ни кыланган була.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Вазгыять бозылу, элеккеге тәртибен югалту. *Бер дә Гафият дигәнчә булмады: каяндыр бу аклары килеп чыкты, дөнья туарылды да китте.* И.Гази

6) *күч.* Сүлпәнләнү, эшкә ваемсыз карау; рухи яктан йомшау. *[Әбҗәлилев] ирешкән уңышлары белән канәгатьләнеп калмады, бервакытта да эшеннән туарылмады.* Г.Шамуков. *Урамда күпме трай тибеп йөрүче, туарылган балачага, яшьләр бар.* Ватаным Татарстан

7) *күч.* Күңел сүрелү, кире уйлау, уйлаган уй-фикереннән кире кайту. *Шәриф абзыйга ат җиктереп, артлароннан чаптырырга уйлаган иде дә, ул планнан рәт чыкмасын белгәч, тагын туарылды.* А.Алиш

**2. туарылып** *күч. рәв. мәгъ.* Рәхәтләнеп, иркенләп. *Аннары райком секретаре булган җирдә туарылып сөйләшеп булмый.* М.Мәһдиев. *Бушанып, туарылып елады.* Г.Гыйльманов. *Рафаэль шулкадәр ихлас һәм бар дөньясын онытып, туарылып көлә иде ки, моны бер тапкыр гына булса да күрергә, ишетергә кирәк.* Р.Мөхәммәдиев

**Туарыла бару** Торган саен ныграк туарылу

**Туарыла башлау** Туарылырга тотыну. *Мортаза туарыла да башлады. Иң элек йон эчле бияләен салып, мич буендагы эскәмия өстенә ыргытты. Бүрек тә бияләйләр артыннан очты.* М.Хәсәнов

**Туарыла төшү** Бераз туарылу

**Туарылып алу** Кыска вакытка гына туарылу; бик тиз туарылу. *Хуҗаның югалып торуыннан файдаланып, туарылып алырга да мөмкинлек бар иде.* Т.Галиуллин. *Бераз туарылып алдык, бүтән ул эш кабатланмас, дип аклана-быз.* Идел

**Туарылып бетү** Тәмам туарылу. *Аяк-куллары белән чәбәләнә-чәбәләнә тәмам туарылып бетмичә йоклап та китә алмый ул.* Г.Галиева. *Туарылып беттең бит син, бырат*! Р.Гаязетдин

**Туарылып калу** Берәр сәбәп аркасында туарылу. *Көне буена җыелган кичерешләрдән һәм күз ачкысыз буран-дагы өшү-туңулардан котылгач, ризыклы җылы өйдә Гайния кинәт туарылып, изрәп калды.* Н.Әхмәдиев

**Туарылып китү** Көтмәгәндә туарылу. *Яшьләрнең болай туарылып китүе аны --- куркытты.* Г.Әпсәләмов

**Туарылып кую** Алдан туарылу яки тиз генә туарылу

**Туарылып ташлау** Тиз арада туарылу

**ТУА́-ТУМЫШТАН** *рәв. к.* **тумыштан**. *Туа-тумыштан шәһәр кешесе Бикчурин моның әллә ни тәмен тапмады.* Ф.Хөсни. *Алар туа-тумыштан эшләргә өйрәнмәгән.* Ф.Дәүләтбаев

**ТУБА́** *и. гар. дини* Тамыры югарыда, ботаклары аста дип ышанылган җәннәт агачы. *Әхмәдияр белән Фәрхизә олпат талларны борынгы тугайның күрке итеп саныйлар, хәтта берсен --- туба агачына тиңлиләр.* М.Хуҗин. *Кайсы туба агачына кунды Мәхәббәтнең парлы оясы?* М.Галиев

**ТУ́БА** *и. ит.* Иң түбән регистрлы бакыр уен коралы, бүрәнкәсыман авызлы, боргаланган зур торба. *Тубада бик көчле, каты һәм дәһшәтле, куркыныч тавышлар чыгарырга мөмкин.* Ә.Бакиров. *--- балалар флейта, туба, саксофон, гармун, ксилофон кебек уен кораллары белән дуслыкларын аерым чыгышларында күрсәттеләр.* Сабантуй

**ТУБАЛ** *и.* 1) Агач кабыгыннан ясалган киң түгәрәк яки ярымтүгәрәк савыт. *Аннан герман атларын җигеп җир сөрделәр, ат җитмәгән сабаннарга үзләре җигелеп йөрделәр, тубал белән орлык чәчеп күрсәттеләр.* М.Мәһдиев. *Дамир белән икесе дә битлек киеп җибәрделәр һәм, кулларына төтен өрдергеч белән күч салыначак тубалны күтәреп, тал башына үрмәләделәр.* Ф.Яруллин

2) Төрле зурлыкта тал чыбыгыннан үрелеп, сибелүчән әйберләр ташу өчен, шулай ук каз оясы итеп кулланыла торган савыт. *Тубал белән кибәк ташу*

3) Бал корты күчен яңа умартага күчерер өчен, гадәттә киндер тарттырылган тырыс

4) Шундый бер савытны тутырырлык булган әйбер микъдары, шуңа тиң үлчәү берәмлеге. *Мин шул йомырка өчен, бер тубал кибәк өчен, бер кочак салам өчен --- дустлаша, бозылыша, сүгешә, сугыша торган кешеләр дәрәҗәсенә төштеммени?* Г.Исхакый. *Аннан соң бер тубал җәүһәргә дә бер түтәрәм икмәк алышучы тапмадым.* Г.Хөсәенов

◊ **Тубал башлы** Зур башлы, тузган чәчле. *Ул аю гәүдәле, имән муенлы, тубал башлы, кирпеч битле ---.* Х.Камалов. *Тубал башлы шушы сабый малай актыгы, чытлым да күзен йоммыйча, аңа туп-туры карап тора бирә.* Р.Батулла. **Тубал бәйләү** Кунакка чакырышу. *--- борынгы заманда --- Тубылтора кирмәне булган, шунда безнең*

*ата-бабаларыбыз «тубал бәйләгәннәр»* ---. И.Хуҗин. **Тубал битле** Зур, җәенке битле. *[Солдатлар] бар да озын мыеклы, бар да тонган күзле, бар да тубал битле.* Х.Кәрим. **Тубал тегү** Бик каты гырлап йоклау. --- *борынгы заманда Тубыл-тора кирмәне булган, шунда безнең ата-бабаларыбыз «тубал бәйләгәннәр», аннан соң «тубал теккәннәр».* И.Хуҗин. *Кызарып кояш чыкканда, барлык кеше тирән йокыда иде. Өйдәге сәкедә, иске тубал теккәндәй гырылдап, Заһри кода йоклый, аның бугазыннан әллә ниткән авазлар чыга.* М.Мәһдиев. **Тубал хәтле (кадәрле)** Зур гына. *Имештер, бер кешегә төн уртасында кырда тубал хәтле ут очраган.* И.Гази. *Фрум белән Ребест аларның нәкъ аяклары биеклеге, ә ул аяклар өстендә торак йорт кадәр гәүдә, ә озын һәм юан муен өстендә, биектә-биектә, тубал кадәрле бик зур баш.* Р.Мөхәммәдиев. *Усаклар арасына кереп киткән кызның башы тубал хәтле булды.* Р.Камал. **Тубалы белән ут төшү** Башка зур кайгы, мәшәкать килү (гадәттә кирәкмәгән эш, чакырылмаган кунаклар һ.б.ш. турында әйтелә)

**ТУБАЛАК** I *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан ак, сары яки шәмәхә чәчәкле, каурыйсыман яфраклы, бармак башы хәтле бәрәңгесе була торган болын үләне; агулы үсемлек; *русчасы:* **мытник**. *[Шкафта] дарчин майлары, тубалаклар, әфьюн һәм башка москатель нәрсәләр [ята].* Г.Камал

**ТУБАЛАК** II *и. диал. к.* **тубал**. *Бер тубалак карабодай чәчү*

**ТУБАЛА́У** *ф. сир.* Берәр эшне бүтән беркайчан да эшләмәскә тәүбә итү

**ТУБАЛБАШ** *и.* 1) *диал. к.* **тукранбаш**

2) *күч.* Зур башлы, тузган чәчле кеше турында әйтелә. – *Кара әле, тубалбаш, сине юкка гына Гений дип атамаганнар икән, – аркасыннан кагып, Мәхмүт аны мактап та алды.* И.Салахов. *Шул тубалбаш татар Нуриев Куба гражданкасы Минея белән өйләнешергә йөри икән!* Р.Батулла

**ТУБАЛЛАНУ** *ф.* Артык күп уйлаудан яки тавыштан баш авырту; баш кату

**Тубаллана бару** Торган саен ныграк тубаллану. – *Монда бит, йокыдан торгач, кайсы уголга барып төртеләсеңне белмисең. Калай кучат әфтияген күбрәк ятлаган саен, баш тубаллана бара. – Киресенчә, аның сүрәләрен укыгач, акыл ачыкланырга тиештер, – дип ачы көлемсерәде Муса.* Идел

**Тубаллана башлау** Тубаллану билгеләре сизелү

**Тубалланып бетү** Тәмам тубаллану

**ТУБАЛЛЫК** *с.* Тубал өчен ярый торган, бер тубалга җитәрлек. *Бер тубаллык туз җыю*

**ТУБА́Л-ТУБАЛ** *с.* **1.** Зур-зур, тубаллар рәвешендәге

**2.** *рәв. мәгъ.* Тубаллап, тубаллар рәвешендә. *Бакчаның ярты өлеше, көнбатыш ягы, астан алып өскә кадәр тубал-тубал булып утырган алмагачлар белән [капланган].* Н.Фәттах. *Бу сәхрә гөж килеп тора: урман аша гына яткан Хлебороб хахулларының әрсез, эре кортлары тубал-тубал булып өерелеп, чәчкә күзләреннән бүгенге көннең соңгы балын эскәкләп җыя.* А.Хәлим

**ТУБА́ЛЧӘЧӘК** *и. бот.* Төнбоек; *русчасы:* **кувшинка**. *Алтын сары тубалчәчәк Чыккан күлнең астыннан.* Ш.Маннур. --- *борынгы заманда тубалчәчәкләр үскән елга буенда Тубылтора кирмәне булган* ---. И.Хуҗин

**ТУБАЛЧЫ** *и.* 1) Тубал ясаучы кеше. *Тубалчыдан тубал сатып алу*

2) *тар.* Элекке заманда, үз товарларын тубалга салып, бер авылдан икенче авылга йөреп сату иткән вак сәүдәгәр; кырыктартмачы. *Авылга килгән кырыктартмачы, тубалчыларга да беренче сорау шул була.* З.Бәшири. *И кыз гына! Ни монда тубалчылар белән маташасың? Тиз бире кил.* М.Акъегетзадә

3) Тубалга салынган орлыклык ашлык бөртекләрен җиргә сибеп баручы, чәчүче. *Минем бригадамдагы биш тубалчы карт, ике чәчү машинасы --- сезнең әмерегезне көтеп торалар.* Т.Гыйззәт. *[Шәйморат:] Мин шулай уйладым инде. Эш тубалчыларда гына. Колачларын җәеп, адымнарын зурайтып атлаганда, байтак кына экономия ясарга була.* Ш.Хөсәенов

**ТУБДИСПАНСЕР** *и. рус* Туберкулёз диспансеры. *Китапханәдән кайтышлый мин тубдиспансер янында Сәетне очраттым.* И.Салахов. *РКБдагы тубдиспансерда утыз бер ел операция сестрасы булып эшләү дәверендә, авылдан димим, аны эзләп, районнан күпме кеше ярдәм сорап барды икән?* Ватаным Татарстан

**ТУБЕРКУЛЁЗ** *и. лат.* Үпкә, сөяк, буын һәм эчәкләрне зарарлый торган йогышлы авыру. *Гыйззәтнең төп йортта бердәнбер сеңлесе Сөембикә гомере буе үпкә туберкулёзы белән иза чикте, санаторийларга бармады, врач дәвасын санга сукмады, үзен сакламады.* М.Мәһдиев. *Медицина хәзер туберкулёзны тулысынча дәвалый.* Н.Фәттах

**ТУБЕРКУЛЁЗЛЫ** *и.* Туберкулёз белән авырый торган. *[Бибиҗамал апа] йөри торган кызының туберкулёзлы икәнлегенә улын ышандырудан ваз кич[те].* Ш.Хөсәенов. *Туберкулёзлы кеше инде бу җәмгыять кешесе түгел.* Р.Батулла

**ТУБЫК** *и.* 1) Аякның балтыр сөяге белән табан сөякләре тоташкан һәм ике яктан кабарыбрак торган урыны (аркылы сөяк). *Тизрәк барып стенадан портретны алды. Аны идәнгә куймакчы булды, әмма идәндә тубыктан су иде.* Ф.Яруллин. *Шуннан соң аягының тубыктан түбән ягы тәмам эштән чыгып калды.* В.Нуруллин

2) *диал.* Тез башы, тез. *Минем туган якта тубык дип тез башына әйтәләр.* Н.Фәттах

**ТУБЫКА** *и. бор.* Тезне бәрелүдән саклау өчен махсус эшләнгән капкач; тез калканы, тез саклагыч

**ТУБЫ́К БАШЫ** *и. диал.* Тез башы. *Тез башы урынына кайчагында тубык башы дигән сүз дә кулланыла.* Н.Фәттах

**ТУБЫКЛАНУ** *ф. диал.* Тезләнү. *Тубыкланып, амин тоткан кебек, Серле суын эчәм кушучлап.* Н.Нәҗми. *Шунда үсмер егет йомшап китте, аякларының мамыкка әйләнүен тойды, тубыкланырга мәҗбүр булды.* З.Мурсиев

**ТУБЫК СӨЯГЕ** *и. анат.* Аяк табанының үкчә өстендәге сөяге; ашык сөяге. *Тездән түбәнге тубык сөяге дә туптай кабарынкы, калку.* Н.Фәттах.

*Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә, тубык сөяге авыртырга мөмкин.* Мәдәни җомга

**ТУБЫЛГЫ** *и. бот.* **1.** Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан хуш исле аксыл сары яки алсу чәчәкле, бик чыдам кызыл сабаклы болын үләне; *русчасы:* **таволга**. *Тубылгыдай агач озын булмас, Тубылгылар аша юл булмас ---.* Җыр. *Бүген сазлык ризыклары белән таныштырмакчы, пошилар үлеп яраткан тубылгы һәм язгы гаҗәп матур сары чәчәкле тавык үләне белән сыйламакчы иде.* М.Рәфыйков. *Тагын язлар җитте. Тубылгылар бөре ача башлаган.* Г.Сабитов

**2.** *с. мәгъ.* Шул үсемлек сабагыннан эшләнгән. *[Егетләр] каеш белән буган билләренә тубылгы саплы, тугыздан түгәрәкләп үргән камчы кыстырганнар.* И.Салахов. *--- кара атның өстендә --- эшлия, җиңел камыт, нечкә тубылгы дуга, тар каештан эшләнгән --- җүгән, аның тезгенен икегә аерып, дуганың ике ягына тарттырып куелган тасма дилбегә.* Р.Әмирхан

**ТУБЫЛГЫЙ** *и. диал. бот. к.* **тубылгы**. *Хәтфә келәм өстенә күпертеп эшләнгән каралҗым яшел чәкәннәр төсле, күзләрне иркәли торган уйдым-уйдым тубылгый болынлыклары күренә.* Ш.Камал

**ТУБЫЛДЫК** *и. диал. бот. к.* **тубылгы**. *Җиккән генә атым туры ала, Тубылдыккайларга урала.* Җыр

**ТУБЫЛДЫРЫК** *и. бор.* Сугыш атының тезләрен бәрелүдән саклый торган тез калканы, тез саклагыч

**ТУБЫР** *и.* **1.** 1) Үсемлекләрдә һәм хайваннар тәнендә түгәрәкләнеп калкып тора торган оры, төер, шеш. *Тубыр – туп кебек кабарып торган шешне, төерне аңлата.* Н.Фәттах

2) Авыр эштән яки йөгерүдән соң тирләгән, ял итеп өлгермәгән атка су эчерткәч барлыкка килә торган авыру, аякка су төшү. *Атка тубыр булу*

**2.** *с. мәгъ. куч.* Үткен, ачы; армас (телле). *Былбылның өне бар, Тургайның тубыр теле бар.* Мәкаль

**ТУБЫРЛАНУ** *ф.* Төерләнү, орылану; тубыр белән каплану. *Агачның тубырланган кабыгы буйлап агып төшкән яңгыр суы Газинның уттай кызган башын рәхәт салкынайтып тора.* М.Хәсәнов. *Кызның шиге дөрескә килде. Күп тә үтми, Күбәләкнең аяклары тубырланды. --- Мондый чакта атны акрынлап йөртергә, аякларын язарга кирәк.* М.Әмирханов

**Тубырлана башлау** Тубырлар барлыкка килү

**Тубырланып бетү** Тәмам тубырлану. *[Гәүһәр] тырнаклары ярылып, буыннары тубырланып беткән бармакларын шунда ук артына яшерде.* А.Гыйләҗев. *Кайнарланып китеп, чүп-чар куакларны гына түгел, тубырланып беткән карт имәннәрне дә аударырга маташкаладым.* Н.Нәҗми

**Тубырланып тору** Тубырланган халәттә булу

**ТУБЫРЛА́У** *ф.* 1) Каты шеш, тубыр чыгу

2) Аякларына су төшкәч йөри алмас хәлгә килү. *Ат тубырлаган*

**Тубырлап китү** Кинәт, көтмәгәндә тубырлау. *– Тик, кем әйтмешли, солы үз урынында, печән үз урынында калсын әле, аларны буташтырмыйк, бахбаебыз тубырлап китмәсен, – диде, ниһаять, киная белән рәк.* М.Әмирханов

**ТУБЫРЛЫ** *с.* 1) Тубырлары, төерләре булган. *Фәрхетдиннәрнең мунчасы турындагы тубырлы кабыклы карт өянке башына саесканнар сарган.* А.Гыйләҗев

2) *куч.* Үткен, ачы; армас (телле)

◊ **Тубырлы алаша** *гади с.* Акрын кыймылдый торган, мыштырдык, эшкә ярамый торган кешене ачулану, тиргәү сүзе. *[Җомабикә:] Ах, мин ул карт ишәкне, тубырлы алашаны!* Т.Гыйззәт

**ТУБЫРСЫК** *с.* Җәенке, киң, тулы. *Улым, бигрәк тубырсык битле син, --- кызлар яратмас инде үзеңне.* М.Хуҗин. *Беренче тапкыр өйләренә алып кайткач, озын буйлы, төскә-биткә чибәр улы янәшәсендә тубырсык гәүдәле, ямьсез хатын күреп, артына егылып китә язудан куркып, урындыкка утырды.* Мирас

**ТУБЫРСЫКЛАНУ** *ф.* Җәенкеләнү, киңәю. *Йөзе ябыкмаган, киресенчә, калынайган-тазарган, юк ла, ишелеп үк җәелмәсә дә, тубырсыкланган икән.* М.Хуҗин

**Тубырсыклана башлау** Тубырсыклану билгеләре сизелү

**Тубырсыкланып бетү** Тәмам тубырсыклану

**Тубырсыкланып китү** Көтмәгәндә, кинәт тубырсыклану

**Тубырсыкланып тору** Тубырсыкланган халәттә булу

**ТУБЫРСЫКЛЫК** *и.* Тубырсык булу сыйфаты. *Хәзер ябыга да төштем, тубырсыклык бетте дә кебек.* М.Хуҗин

**ТУБЫРЧА** *и.* Әвернәдән җеп урау өчен ясалган кыса. *Эшсез калган әниләре Сылу җиңги өйалдыннан әвернә тактасы белән тубырча алып кереп, идән уртасынарак киләпне сүтеп чолгарга утырды.* М.Галәү. *Әзер җепне тубырча дип аталган станокта аркылы һәм буй җепләргә аерганнар.* Р.Рәхимова

**ТУБЫРЧЫК** *и. диал.* 1) Нарат, чыршы һ.б. ылыслы агачларның күркәсе. *Өч йөз алтмыш биш сыерчык, Илле ике тубырчык, Унике аккош, бер торна – Ул сүзне уйлап күп торма.* Табышмак. *[Артыш] аталан[гач], яшькелт чәчәкләр урынында ямь-яшел тубырчыклар пәйда була.* Г.Хәсәнов

2) Мичкә бөкесе. *Агач тубырчык*

3) *куч.* Тыгыз, тулы тәнле, хәрәкәтчән, елгыр бала

◊ **Тубырчык тибү** *к.* **тырай тибү**. *Ә мин нәрсә, урам буйлап тубырчык тибеп йөримме?* Ялкын

**ТУБЫРЧЫН** *и. к.* **тубырчык** (*2 мәгъ.*). *Чүпрәк тубырчын*

**ТУВА** *и. иск. к.* **тыва**

**ТУВА́ЧА** *рәв. иск. к.* **тывача**

**ТУВА́ЧАЛАП** *рәв. иск. к.* **тывача** (*1 мәгъ.*)

**ТУВЧӘ** *ы.* Мөгезле эре терлекне куганда әйтелә. *Тувчә!.. Ай, --- ышкынып, читәнне аудара бит инде. --- Тувчә! Эченә казык кергере сыер...* М.Фәйзи

**ТУГ** *и. бор. к.* **ту** I (*1 мәгъ.*)

**ТУГАЙ** *и.* 1) Елга ташканда су баса торган үзәнлек (гадәттә ярымутрау рәвешендәге). *--- безне әллә кайдан кая җәелеп яткан киң тугай чык суы белән энҗедәй ялтырап каршы алды.* Г.Ибраһимов. *Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы,*

*киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.* Ә.Еники

2) Елганың дугасыман бормалы урыны. *Борылып аккан су буйларын тугай диләр, Төрекстанда татарларга нугай диләр.* Шура. --- *ярдагы талларны кышлыкта утынга кисеп бетерәләр, елга ишәеп кала, киңәеп, бер урында иркен сулыш ала – тугай ясый ---.* Г.Гайнуллина

**ТУГАЙЛАНУ** *ф.* Дуга шикеллерәк бормалану. *Монда, Чулман яры тугайланып эчкә кергән җирдә, су өстендә унлап көймә тора иде.* Н.Фәттах. *Арырак Ашытның алтын көзгесе тугайлана.* Р.Фәизов

**Тугайлана бару** Акрынлап тугайлану

**Тугайланып килү** Торган саен ныграк тугайлану. *Ул тугайланып-тугайланып килгән текә яр буйлары, чиксез зәңгәр су киңлеген ерып барган ак җилкәнле көймәләр һәм ял итүчеләрне төягән, күңелле музыка авазлары тараткан ап-ак пароходлар.* М.Вәлиев

**Тугайланып тору** Тугайланган хәлдә булу. *Шул төштә инеш әз генә тугайланып тора иде.* Х.Камалов

**ТУГАЙЛЫ** *с.* 1) Тугае булган. *Украина иле тугайлы, Тугайлары озын курайлы.* М.Җәлил. *Нияте изге була: --- шактый илләр белән сәүдә итеп яткан Идел буе Болгарына кайта һәм Казан каласы белән Арча арасындагы яшел тугайлы --- калкулыкны ыстаны итә.* М.Хәбибуллин

2) Бормалы, тугай-тугай. *Тугайлы елга буйлары*

**ТУГАЙЛЫК** *и.* 1) Елга яры буендагы уйсу җир, үзәнлек; болынлык. *Ниндидер тугайлыктан тездән үләнне ерып кайтып килә имеш.* М.Мәһдиев. *Торна елгасы диген сөзәк бер тугайлык аркылы салынган арба юлына бордырып алдык.* К.Миңлебаев

2) Елганың дуга сыман бормалы урыны

**ТУГАЙТУ** *ф. диал.* Тук итү, тук хәлгә китерү. *Муллалык доходы җитмиме? --- Рәхим итеп, тугайта торган эш эшлә.* Ф.Әмирхан. *Аракы тугайтмый, канишны.* Р.Кәрами

**ТУГА́Й-ТУГАЙ** *с.* **1.** Бормалы-бормалы, дуга сыман. *Идел буе тугай-тугай, Тугай саен бер тургай.* Җыр. *Укытып, җырчыларны бозалар гына. Сарман буйкайлары тугай-тугай, Тугаенда сайрый бер тургай-а-а-ай. Монавы кадәр матурлыкны ничек ташлап китмәк кирәк?* А.Хәлим. *Авыл халкы, безнең сулар тугай-тугай, ат сугарырга уңай, дип җырлый.* Х.Садри

**2.** *рәв. мәгъ.* Бормалы-бормалы булып. *Балыкчының урамы Тугай-тугай әйләнгән.* Бәет

**ТУГАН** *с.* **1.** 1) Турыдан-туры кан кардәше булган. *Сарсымбайның туган энесе Асылҗегет исемле берәүгә баладан үземне әйттергән булганнар.* Г.Ибраһимов. *Әлбәттә, әтисе, яисә туган абыйсы хөрмәтеннән чакыра инде аны Мансур Ибраһимович.* Х.Ширмән

2) Дөньяга килгән, туып үскән (урын тур.). *Кырык дүртнең көзендә яраланган Әхтәри, тылдагы госпитальдән фронтка үтеп барышлый, туган шәһәрендә бераз кунак булып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Ташлы Кавал – Өммегөлсем әниемнең туган авылы.* А.Хәсәнов

3) Дөньяга килгән; барлыкка килгән (вакыт тур.). *Ул арада теге элеккеге дуслар да читләшә башлый: инде телефоннан чылтыратмыйлар, туган көнең белән котларга оныталар ---.* М.Мәһдиев. *Инде әти гүр иясе булганга берничә ел үтте. Югалтуларга күнегәсең икән. Каберләрнең, шагыйрь әйтмешли, туган елы гына бар шул.* Т.Галиуллин. *Яңа ай туган вакытларда бу тирәдән үтеп китәргә курыкканнар.* Х.Садри

4) *күч.* Бер милләттән булган, йөрәккә якын; кадерле. *Каләм ясап каурыеңнан язгы ялкында, Ут эченнән бер җыр языйм туган халкыма.* Х.Туфан. --- *мин, шәхес буларак, үз дәрәҗәм, үз урынымны ачыкларга теләсәм, беренче чиратта, туган халкым турында – аның тарихы, бүгенгесе, киләчәге турында уйларга тиеш булам.* Р.Миңнуллин

5) *күч.* Үзенеке, тумыштан бирелгән; үз халкыныкы, милләтенеке. *Шунда су күп эчә торган Танябыз идәнгә яткан да ишек астындагы ярыктан «И туган тел, и матур тел» дип җырлап ята.* Ф.Яруллин. *Сабый җанын аңлап, туган тел кануннарын тоеп язылган шигырьләр генә бала күңеленә барып җитә ала.* Р.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Беренче дәрәҗәдә, иң якын, кан кардәш. *Гади генә тормышыма ямь өстәп, күрше авылдан туганым килеп төште.* Д.Гайнетдинова. *Инде кайтам дисә – әнисе, барам дисә – әтисе юк аның. Ичмасам, я кыз, я ир туганы булсын икән.* Р.Гариф

2) Бер нәселдән булган кеше. *Флүр Сәхәбиевич авыл белән араны өзмәде, туганнары килсә, кунак итте ---.* Р.Кәрами. --- *бөтерчек кебек хәрәкәтчән түтәй Марина Михайловна пристаньда безне бик җылы каршылады, өйгә кайткач та, якын туганыдай, кадерләп кунак итте.* С.Сабиров

3) Ир кешегә карата үз итеп, дусларча әйтелә торган эндәшү сүзе. *Шәйхиев дәшми торыбрак тагын сорады: – Минем бурыч нидән гыйбарәт? – Сездән мин, Идеал туган, бер генә нәрсә ишетәсем килә: кульязма шушы хәлендә нәшриятка тәкъдим итәрлекме-түгелме?* Ә.Еники. *Син кайтканны алар айлар буе көтеп утырырлар дип уйлыйсыңмы? Ялгышасың, туган, синең белән миндә булган нәрсә бүтәннәрдә дә бар.* Р.Сәгъди

4) *күч.* Дус; фикердәш кеше; мәнфәгатьләре, тормыш шартлары яки яшәү рәвеше уртак булган кеше. *Ул тавышлар килгән якка атлады да гозерен чыгарып та салды: – Мөселман туганнар! Дүрт ятим баланы Ырымбурга хәтле үзегез белән алыгыз әле.* З.Зәйнуллин. *Өйгә кайтып сулу алган минутларында тагын бер көйне бик яратып уйный ул. --- «Гөлнәзирә» көе ул, башкорт туганнар көе.* Д.Гайнетдинова

◊ **Туган җанлы** Туганчыл, туганнарына шәфкатьле, туганнарын ярата, якын күрә торган. *Җиңгәсенең шулай туган җанлы булуы, өзгәләнеп каршы алуы Һадиның күңелен йомшартып җибәргәндәй итте.* М.Хәсәнов. *Холкы азрак кырыс инде кырыслыкка. Шулай булса да, мәрхәмәтле, туган җанлы ул бабакаең.* З.Зәйнуллин. *Болар – минем иң яраткан туганнарым. Алар үзләре дә бик туган җанлылар.* Казан утлары.
**Туганнар кабере** Сугышта яки бәла-

каза вакытында һәлак булганнарның гомуми кабере. *Күмелгән урыны Курск өлкәсе Рыльски районы Костровка авылы янында, туганнар каберендә...* Ә.Еники. *Намаз укып бетергәннән соң, ул туганнар каберенең гадәттән тыш зур чокырын күмәргә экскаваторчыга әмер бирде.* Я.Шәфыйков. **Туганнар каберлеге** Сугышта яки зур бәла-каза вакытында һәлак булганнарның гына каберләре урнашкан махсус зират. *Бәлки, ул өзек аяклар, мәетләр белән бергә җыештырылып, туганнар каберлегенә күмелгәндер...* Җ.Юныс. *Кичә мин әбием белән зиратка бардым, бабам каберенә чәчәк салдым, аннары туганнар каберлегендәге исемлек янында тордык, таныш исем эзләдек...* Г.Гыйльманов. **Туган сарылы** *к.* **туган җанлы**

**ТУГАНАЙ** *и. сөйл. к.* **туганый**. *Туганай, әни бик тәмле талкан болгатты, ашарга кер!* Т.Гыйззәт. *Хикмәт шунда, туганай: ошбу галим кәмпүтердән синең геннарыңны тикшергән.* Ф.Баттал

**ТУГА́Н АПА** *и.* 1) Әнисе яки әтисенең кыз туганы. *Туган апа аша ул безне күреп сөйләшәсе килүен белдергән.* Г.Каюмов

2) Бертуган абыйсының хатыны, җиңги

**ТУГАНДАШ** *с.* **1.** Иптәшлеккә, дуслыкка нигезләнгән, мәнфәгатьләре уртак булган. *Хәзер инде тугандаш республикаларда да профессор Идеал Шәйхиев дигән исемне яхшы ук беләләр.* Ә.Еники. *Икенче елны, тугандаш дәүләтнең иминлеген саклаганда, Гөлнәзирәне дә әнисе кебек тол калдырып, ире һәлак булды.* Р.Кәрами

**2.** *и. мәгъ.* Милли яки дини уртаклыкларга ия булган халыкка карата кулланыла. *Алар бер кешеләрен, тугандашларының хәлен белеп килү өчен, --- татар җәйләвенә кайтарып җибәргәннәр.* Р.Фәхретдинов. *Бу телләр, төрки исәпләнелсәләр дә, үз тугандашларыннан бик нык аерылалар.* Н.Фәттах

**ТУГАНДАШЛЫК** *и.* 1) Тугандаш булу, дус яшәү хәле. *Анда абориген һәм килмешәк халыклар арасында тугандашлык бәйләнешләре булмый.* Б.Хәмидуллин. --- *шушы ике кыйтганың, --- ике дөньяның бер үк вакытта үзенчәлекле аерымлыгын тоюны да, шул ук вакытта аларның җанкүңел һәм хис-фикер аша олы тугандашлыгын аңлауны да --- без Рәдиф Гаташ шигъриятендә ачык табабыз.* И.Вәлиулла

2) Туганнарча мөнәсәбәт, бердәмлек

**ТУГАНИ** *и. сөйл.* Хатын-кызлар арасында бер-берләренә яратып эндәшү сүзе. *Минем бик дус бер кызым: «Әй тугани (без аның белән бер-беребезгә тугани дип йөри идек), кешенең сөйләгәнен күрсәң, бөтенләй исең-акылың китәр», – [диде].* С.Җәлал. *[Апам белән] Күрешеп хәл белешкәч тә, әйдә, тугани, чәй белән сыйлыйм үзеңне, дип, китапкулъязмаларны веранда өстәленең аргы башына шудырдым.* К.Миңлебаев

**ТУГАНИ́ АБЫЙ** *и. диал.* Олырак яшьтәге якын ир кардәшне атау яки эндәшү сүзе. *Әниемнең биш ир туганына дәү абый, кечкенә абый, тугани абый, матур абый, тәти абый дип эндәшә идек.* Ак калфак

**ТУГА́Н-КАРДӘШ** *җый. и. к.* **туган-тумача**. *Миңа шул туган-кардәшне бер күреп, сөйләшеп, үз туган туфрагымда үлсәм, башкасы кирәкми.* Н.Исәнбәт. *Малсыз булсаң, туган-кардәш ят булыр.* Безнең гәҗит

**ТУГАНЛАШТЫРУ** *ф.* Туганлык, дуслык мөнәсәбәтләре булдыру. *Димәк, дача күршеләре! Үзебез генә түгел, көрәкләребез дә, балта-пычкыларыбыз да туганлашырга тиеш дигән сүз бу.* Ф.Баттал. *Зөләйха аларны кабат туганлаштырды, татулаштырды, бер гаилә итеп бөтенәйтеп куйды.* Г.Гыйльманов

**Туганлаштырып кую** Тиз арада туганлаштыру. *Икесенең дә балалар йортыннан булуы бу минутта аларны нык кына якынайтып, хәтта туганлаштырып куйган иде.* Г.Гыйльманов

**Туганлаштырып тору** Туганлаштыруга хезмәт итү. *Мәчет – милләтне берләштереп, туганлаштырып тора торган бер урын, бу – читтә бигрәк тә нык сизелә.* Ф.Бәйрәмова

**ТУГАНЛАШУ** *ф.* 1) Нинди дә булса кеше яки кешеләр төркеме белән туганлык (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтенә керү. *Күрән бинең Биар ханы белән туганлашасы килә.* Н.Фәттах. *Ипидә кешеләрне бер-берләре белән туганлаштыра торган көч бардыр, күрәсең.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Якын дуслык мөнәсәбәтләренә керү, дуслашу. *Без кул күтәрәбез! Төрле милләтләрнең Туганлашкан, бердәм Хезмәт халкы өчен!* М.Җәлил. *Бөек Ватан сугышы чорында туганлашкан өч дәүләт: Англия, АКШ һәм СССР, сугыш бетүгә, корт чаккандай як-якка сибелә.* Р.Садриев

3) *күч.* Фронтта каршы якларның солдатлары үзара бердәмлекне, фикердәшлекне белдереп, хәрби хәрәкәтләрне, сугышны, көрәшне туктату, татулашу күренеше; *русчасы:* **братание**. *Немецларның рядовой солдатлары хәзер һәр көн безнең белән туганлашып торалар. Алар да бу канлы сугышка чик куеп, туган җирләренә кайтып, тыныч көн күрү юлына керү сәгатьләрен көтәләр.* М.Гафури

**Туганлаша тору** Башка бер эшгамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта туганлашу; әледән-әле туганлашу. *Күпләре биредә сыену урыны гына түгел, үзләренең бердәнбер ярларын тапты, башлы-күзле булды. Шулай итеп ике ыру кушылып туганлаша торды.* Р.Сәгъди

**Туганлашып бетү** Бөтенләй туганлашу. *Менә дистә еллар буена шулай дәвам иткәч, ырулар инде туганлашып та бетәләр.* Р.Сәгъди. *Көн саен мәйданга йөреп, митингдашлар инде тәмам туганлашып беткәннәр, килү белән үзара кул бирешеп күрешеп чыгалар.* К.Кәримов

**Туганлашып карау** Туганлашырга омтылыш ясау

**Туганлашып киту** Билгеле моменттан башлап, тиз арада туганлашу. *Бу минутта Сәлимгә булган элекке ачулары тәмам онытылган, ә Сәлим аңа ничектер якынаеп, туганлашып киткән кебек иде.* Г.Әпсәләмов. *Җиңелгәннән соң, болгарлар җиңүче татарлар белән туганлашып китә, --- уртак никахлар да күбәя ---.* Р.Батулла

**Туганлашып кую** Кинәт, тиз арада ниндидер сәбәп аркасында туганлашу. *Балаларыбыз бергә үсеп, тора-*

*бара туганлашып куюыбыз да бар.* Ф.Тарханова. *Әнә шулай француз Анри Лакманның «кадерле дустым» дип башланган чыгышыннан соң ике җитәкче туганлашып та куйды.* Ватаным Татарстан

**ТУГАНЛЫК** *и.* 1) Кардәшлек. *--- туганлык җебе, еллар үткәч тә, яңадан ялгана ала ---.* М.Галиев. *Мишәрләрдә бердәмлек һәм туганлык хисе көчле, диләр.* Ю.Сафиуллин

2) *күч.* Үзара дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтләре, бердәмлек, бергәлек. *Максат милләтләр арасында дуслык, татулык, туганлык тәрбияләү ләбаса!* А.Хәсәнов. *--- Критның Кече Азия белән туганлык элемтәләре нык һәм дәвамлы булган.* Н.Фәттах

**ТУГАНЛЫКЛЫ** *с.* Туганнарын якын күрүчән, туган итүчән; туганчыл. *Ярый әле Сәгыйдә бар. Бераз аңа юаныч: ышанычлы, туганлыклы, сердәшче йөрәк...* Х.Туфан. *Туганлыклы булып үсү*

**ТУГАНЛЫ́К-ТУМАЧА́ЛЫК** *җый. и. к.* **туган-тумачалык**. *«Мөселман иттифакы»на кереп, үзеңне мөэмин вә мөселман дидерәсең килсә, менә шул түбәндәге нәрсәләргә иман китерергә кирәк: 1) байлык, --- 7) кодалык-кодачалык, 8) туганлык-тумачалык.* Г.Тукай

**ТУГАННА́Н ТУГАН** *и.* Әтиләре яки әниләре бертуган булган икенче буын балалар (бер-берсенә карата). *Җәмил исемле туганнан туганым теш врачына укый иде.* Т.Галиуллин. *Бу таза һәм җитез Себер егетләренең икесе бертуган, берсе аларның туганнан туган энеләре иде.* Ф.Булатов

**ТУГАННА́Н ТУМА** *и. диал. к.* **туганнан туган**. *[Унгляубенең] туганнан тума сеңелесе Матильда --- килеп керде.* Ш.Маннур

**ТУГАННА́Н ТУЫШКАН** *и. диал. к.* **туганнан туган**

**ТУГАННА́РЧА** *рәв.* 1) Туганнар, кардәшләр арасында кабул ителгәнчә җылы, чын күңелдән. *Газинур --- Сәлимгә якынрак елышып, туганнарча итеп: – Әллә сәламәтлек шәп түгелме, Сәлим? – диде.* Г.Әпсәләмов. *Сабит, сул кулы белән маңгаен кашый-кашый, номер җыйды, менә аның кырыслыгын елмаю алыштырды, ул ниндидер Иван Иванович белән якын туганнарча хәбәр бүлешергә тотынды.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Иптәшләрчә, дусларга хас булганча. *Без, өч дус, үзара туганнарча саубуллаштык та, өчебез өч якка юл алдык.* Г.Кутуй. *Үзбәк агай-энеләр дә үткәннәрне дөрес анализлап, киләчәктә татарлар белән туганнарча мөнәсәбәт урнаштырырлар, дип өметләник.* Т.Миңнуллин

**ТУГА́Н-ТУЛПЫ** *җый. и. диал. к.* **туган-тумача**. *Сабан беткәннең икенче көнендә --- тәкәне суеп, туган-тулпы, күрше-күләнне җыйдык.* Х.Сарьян

**ТУГА́Н-ТУМА** *җый. и. к.* **туган-тумача**. *Ичмасам, кешегә ашап-эчәргә, туган-тумалары белән бәхилләшергә ирек бирсеннәр икән.* Ф.Хөсни

**ТУГА́Н-ТУМАЧА** *җый. и.* Якын туганнар, кардәшләр; кардәш-ыру, нәсел-нәсәп. *Син безнең иң якын кешебез, туган-тумачадан да якынрак кешебез.* Н.Фәттах. *Берәүләр кунак чакырган, икенчеләре үзләре барган, туган-тумача, таныш-белеш җыелган.* Р.Кәрами

**ТУГА́Н-ТУМАЧАЛЫК** *и.* 1) Туганлык мөнәсәбәтләре. *Туган-тумачалык турында җырлыйлар.* Р.Миңнуллин. *Ханнар һәм бәкләр нәселендәге туган-тумачалык та күптәннән килә.* Ф.Хуҗин

2) Хезмәт урыныннан файдаланып, якыннарына яки туганнарына ташламалар ясаудан, аларны үз җитәкчелеге астына эшкә алудан, урынсыз яклаулардан гыйбарәт җитәкчелек принцибы; кода-кодагыйлык, агай-энелек. *Аның сөйләгәне бар: туган-тумачалык, әшнәлек юк, ди, немецларда.* Х.Камалов. *Блат, ягъни мәсәлән, әшнәлек, туган-тумачалык, кода-кодагыйлык кебек төшенчәләр адәм баласының канына, зиһененә ана сөте белән үк сеңә торгандыр, мөгаен.* Т.Галиуллин

**ТУГА́Н-ҮСКӘН** *с.* Тегe яки бу кеше дөньяга килгән, туып үскән (урын тур.). *Туган-үскән илләреңдә Гомер кичерсәң иде.* Җыр. *Кичерелгән җәбер-золымнар һәммәсе искә төшеп, кешеләрдә туган-үскән җирне ташлап китү теләге көчәйгәннән-көчәя бара иде.* М.Галәү. *Әйтерсең лә кыр казлары Җырлап үтте турыбыздан: «Өзелмәсен тамырыгыз Туган-үскән ягыбыздан!»* С.Әхмәтҗанова

**ТУГАНЧЫЛ** *с.* Туган җанлы, туганнарын үз итүчән, якын күрүчән. *[Марилар] бердәм һәм туганчыл иделәр. --- Дошман минасыннан берәр мари егете яраланса, калганнары шуның янына йөгереп килеп, кызганышырга тотыналар.* Ш.Маннур. *Ачык йөзле, хуш күңелле, туганчыл, эшкә батыр, җегәрле һәм сүзгә оста киленнәр Талип авылы халкын рухи яктан асылландыруга шактый өлеш кертте.* З.Мурсиев

**ТУГАНЧЫЛЛЫК** *и.* Туганчыл булу сыйфаты. *Абыйлар мине --- чокырда калдырып кайтып киттеләр. --- Туганчыллык итмәделәр.* Әкият. *Тормыш арбасыннан төшеп калмас өчен дөнья куганда, гадәттә, рухи кыйммәтләр читтәрәк кала, туганчыллык, киң күңеллелек --- кебек сыйфатларның бәясе кими ---.* Мирас

**ТУГАНЧЫЛЛЫКЛЫ** *с. к.* **туганчыл**. *Балаларның үзара дус һәм тату, туганчыллыклы мөнәсәбәттә булулары, хәләл көч белән көн күрергә омтылышлары да – нигездә безнең уртак тәрбиябез нәтиҗәсе.* Татарстан яшьләре. *Туганчыллыклы, бер-берсенә бик ярдәмчел иде алар.* Безнең гәҗит

**ТУГАНЫЙ** *и. сөйл.* 1) Дусларча, якын итеп, үз итеп эндәшү яки атау сүзе; туганкай. *Хатыннар киләләр дә аның белән кул биреп күрешәләр: «Исәнме, туганый, бик исән-сау гына килеп җиттеңме?»* А.Шамов. *Туганый, әнә теге вагонны Казанга чаклы гына алып бар әле.* Р.Кәрами

2) Кечерәк яшьтәге кешегә иркәләп, яратып эндәшү сүзе

**ТУГАНЫМ** *и.* 1) *к.* **туганый** (*1 мәгъ.*). *Әминә, яртылай чишенгәч, барып, бер йомшак эскәмиягә ташланды да: «Кил әле, туганым, алдыма утыр әле», – дип, чишенеп тора торган Хәятны чакырды.* Ф.Әмирхан. *[Әни] Галимәгә карап: «Әйдә, Галимә, туганым, юынып ал, мин самавыр куйыйм»... – ди[де].* М.Гафури

2) *иск.* Бер ир хатыннары яки килендәшләрнең бер-беренә эндәшү сүзе. *[Хатын] сорый һаман: яңалык, ди, Яңа ботинка юк бит, ди, Туганыма алдың*

*бит, ди, Миңа да бир, китер, кайда?* Г.Камал. --- *әни --- көндәш булып килүе белән хастаны бик гарьләндерәсе дә килмәгәнен сиздерә, кире китәргә дә риза икәнлеген белдерә. Әмма --- дөньясыннан тәмам бизгән --- хатын: «Юкны сөйләмә, туганым. Син китсәң, икенче берәү килер, монда йортны алып барырга кемдер кирәк бит инде», – ди.* К.Миңлебаев

3) Иркәләп, яратып әйтелә торган эндәш сүз. *Шатлану куанычыннан авызын җыя алмаган Бәһрам: «И-и туганым! Сине дә исән-имин күрәсе көннәр бар икән!» – дип, Иргалине җилкә-аркаларыннан кагып-сөеп алды.* М.Хәсәнов. *Шул телсез сабыйларның ни гаебе бар, ә, туганым?* А.Хәлим

4) *Апа, җиңги, абыстай* һ.б.ш. сүзләр алдыннан килеп, аларга иркәләү, ярату, хөрмәтләү төсмере өсти торган сүз. *Син генә аңа «туганым җиңги» дип исең китеп йөри.* Г.Камал. *Туганым абыстайны җизни уналты яшендә ала.* Л.Хәмидуллин. *Берсендә туганым апам: – Безне кем кияүгә димләсен, нәселләрендә тилемсәләр бар, диләр дә, бүтәннәргә өйләнәләр, – диде.* Н.Гыйматдинова

**ТУГА́Н-ЫРУ** *җый. и.* Якын һәм ерак кардәшләр, нәсел-нәсәп; туган-тумача. *Ата-анасыз, туган-ырусыз тилмереп калган малайны карашып йөрүеңме, Шәмсәстай?* М.Фәйзи. *Шул хәлләрдән соң туган-ыру арасында Мирхәйдәрне яман чирләр баскан шәһәрдән ераккарак озатып тору теләге туа.* Л.Хәмидуллин

**ТУГАНЫЧЛЫ** *с. сир. к.* **туганчыл**. *Туганычлы кыз*

**ТУГАРУ** *ф. диал. к.* **туару**. *Ахырда, үгезне тугарып, чанага Күк бияне җиктеләр.* Н.Әхмәдиев. *Яр кырыендагы чирәмлеккә атын тугарып җибәрә: «Ашый тор, Аккошым, әле мин бу мичкәгә чиләкләп су тутырганчы, ике тапкыр туеп өлгерерсең».* Ф.Яруллин

**Тугара башлау** *к.* **туара башлау**. *Сабир карт --- тугара башлаган атны тәртә арасында калдырып, Фатыйх янына килде.* Г.Галиев

**Тугарып бетерү** *к.* **туарып бетерү**. *Атын тугарып бетергәч, өстенә Марфадан онытылып калган толыпны ябып, Күк бияне Чулман болынының хуш исле печәненә кушты.* Н.Әхмәдиев

**Тугарып карау** *к.* **туарып карау**. *Тугарып та караганнар, тормаган малкай.* Казан утлары

**Тугарып кую** *к.* **туарып кую**

**Тугарып ташлау** *к.* **туарып ташлау**. *– Бурычыңны бүтән төсле түләрсең соң, ни булган ул чаклы! – дип, бөтенләй тугарып ташлый.* Х.Камалов

**ТУГАРЫЛУ** *ф. к.* **туарылу**. *Авыр сулап, офтанып куйгач, тугарылып, рәхәтләнеп көлә башлады.* Р.Мулланурова

**Тугарыла бару** *к.* **туарыла бару**. *Фәкать сәламәтлеге көннән-көн тугарыла барган ишан исправник хозурына килә алмый, үзенең түшәктә ятуын белдерә.* Р.Әмирхан

**Тугарыла башлау** *к.* **туарыла башлау**. *Разия, иренең тугарыла башлавын сизеп, аңа каш астыннан усал караш ташлады: «И теле, и теле шушының!»* Мирас

**Тугарыла төшү** *к.* **туарыла төшү**

**Тугарылып алу** *к.* **туарылып алу**. *Юк, алтын тәңкәм, бармыйм, синең янда кунарга калам, минем дә тугрылыклы подданныйларым кебек тугарылып алырга хакым юкмыни?* Р.Мирхәйдәров

**Тугарылып бетү** *к.* **туарылып бетү**. *Партия дигән ат-арбаның дирбияләре тугарылып бетеп барса да, кемнәрнеңдер әле дилбегәне нык итеп тотарга тырышып тырмашкан чаклары.* Р.Фәйзуллин

**Тугарылып җитү** *к.* **тугарылып бетү**

**Тугарылып калу** *к.* **туарылып кую**. --- *мин аның алдында җырлый алырлык хәлдә түгел идем инде. Әллә ничек берьюлы бушап, тугарылып калдым.* Ә.Еники

**Тугарылып китү** *к.* **туарылып китү**. *Диңгез буендагы нәни генә курорт шәһәре бит инде, тугарылып китеп, башта – күлмәкне, аннары майканы да салып аттым.* Р.Вәлиев

**Тугарылып кую** *к.* **туарылып кую**. *Тугарылып куйган атларым ---.* Зөлфәт. *Шул кеше, кайтып, йортының ишеген ачып кердеме, тугарыла да куя.* Г.Хөсәенов

**Тугарылып ташлау** *к.* **туарылып ташлау**. Тиз арада тугарылу. *Кичә генә, нишләптер, тугарылып ташлаганмын.* З.Мурсиев

**ТУГАЧ** *и. диал.* Әче камырдан пешерелгән күмәч, әче күмәч. *Тугач пешердем*

**ТУГАЮ** *ф. диал.* 1) Ашап тую, тук хәлгә килү, туйганчы ашау. *Колынкаем кырдан кайта тып-тып басып, тугаеп.* М.Фәйзи

2) Симерү, тазару, көрәю. *Аның казлары тизрәк тугаеп, алданрак куәт җыеп өлгерәләр.* М.Шабай

3) Тук хәлгә килү; өлгереп, җитлегеп, орлыкны, сокны мул туплау (ашлыклар, җимешләр тур.). *Машиналар --- тугаерга торган арыш башакларын көрән җир белән бергә бутап, изеп бетергәннәр.* А.Гыйләҗев

**Тугаеп җитү** Тәмам тугаю

**Тугая бару** Торган саен ныграк тугаю

**Тугая башлау** Тугаю билгеләре сизелү. *Кара син аларны, карт юләрләрне, тамаклары тугая башлаганга шулай итенәләр алар.* Ф.Бурнаш

**Тугая төшү** Бераз тугаю; тагын да ныграк тугаю

**ТУГЛАВЫЧ** *и.* 1) Берәр нәрсәне болгату, туглау өчен эшләнгән махсус җайланма. *Газбетонны җитештергәндә, беректергеч матдә, комлы шлак һәм су катнашмасын үзйөрешле туглавычта 4–5 минут туглаганнан соң, бу катнашмага алюминий пудрасының сулы суспензиясе өстәлә ---.* Төзү материаллары

2) Сыек камыр болгатыр, туглар өчен, төп ягыннан өч-дүрт ябе өскә таба чыгып торган нечкәрәк, кыска таякчык (гадәттә нечкә, яшь чыршы агачыннан шомартып ясала); *русчасы:* **мутовка**

**ТУГЛАГЫЧ** *и. к.* **туглавыч**. *Чи йомырканы сытып, сарысын --- савытка салалар да, тоз сибеп, махсус туглагыч яки калак белән бик яхшылап туглыйлар.* Йорт эшләре. *Циклик эшләүче бетонтуглагыч машиналарның гравитацион һәм мәҗбүри туглагыч төрләре була.* Төзү материаллары

**ТУГЛАНДЫРУ** *ф.* Берәр нәрсәне әрле-бирле китереп йөртү, әйләндерү, бөтерү. *Зират ягыннан искән җилне ка-*

*еннар каплап тугландыралар.* М.Гали. *Археолог, табылма тикшергәндәй, эш коралын әйләндереп, тугландырып бик озаклап өйрәнә дә төзәтә, ямый, сипли башлый.* Т.Галиуллин

**Тугландыра башлау** Тугландырырга тотыну. *Рафаэль, Сәетне күрми, ишетми, ашыга-кабалана төргәкне сүтте, алтынын тугландыра башлады.* Т.Галиуллин

**Тугландыра тору** Башка бер эшгамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта тугландыру

**Тугландырып карау** Нәрсәне дә булса эшләп булу-булмауны тикшерү-сынау өчен тугландыру

**ТУГЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **туглау**. *Беркөн алган аванснең соңгы бөртек оны кичә кичке ашка тугланды.* М.Мәһдиев. *Массаны пластик ысул белән әзерләгәндә һәм аңа форма биргәндә, табигый дымлы хәлдә булган яки киптерелгән материалларга су өстәп, --- измә туглана.* Төзү материаллары

2) *күч.* Бер тирәдә әрле-бирле килеп йөрү, әйләнү, болгану. *Әрле-бирле тугланып эзләп йөреп тә эләктерә алмагач, Фәтхи --- пычагын юлында очраган кырмыска түмгәгенә батыра да аты янына китә ---.* Т.Мөбарәков. *Аксаптуксап йөреп тә кеше күзенә кылчык булып кадалмады, үзен кызганыпкимсетеп караучыларның каршында тугланмады.* Д.Гайнетдинова

3) *күч.* Тәртипсез әйләнү, чуалу, буталчыклану. *Тәэсирләрнең күплегеннән аның тәмам башы каткан, уйфикерләре буталып миендә туглана, ләкин алар, ничектер, эзлекле түгел, бер фикер агышы икенчесен басып китә, аннары анысы да юкка чыга иде.* А.Вергазов. *Бүген минем күңелдә уйлар әйләнде, буталды, тугланды.* Ф.Галиев

**Тугланып алу** Кыска гына вакыт туглану. *Ашкынулы музыка, ишекләрдән, тәрәзәләрдән урамга бөтерелеп чыгып, өермәдәй тугланып ала да, кире кайтып, заманча киенгән егет-кызларны элеп алып селкеп сала.* А.Вергазов

**Тугланып бетү** Тулысынча, тәмам тугланган хәлгә килү. *Башта киңәшмәләр, аннары тикшерүчеләр белән мие тугланып бетте.* Х.Камалов

**Тугланып йөрү** Әледән-әле, даими туглану. *Рюкзак табылган тирәдә сине очратмаммы дип болганып-тугланып йөрдем дә аякларым кая таба атласалар, шунда киттем.* Казан утлары

**Тугланып тору** Хәзер, шушы вакытта яки һәрвакыт туглану

**Тугланып яту** *сөйл. к.* **тугланып тору**

**ТУГЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **туглау**

2) *диал. к.* **туглану** (*1 мәгъ.*). *Чәй янында киптерелгән җир җиләге, бәрәңге салып, бераз он туглаткан сыек шулпа, алабута кушып пешерелгән ипи.* Р.Батулла

3) *диал. к.* **туглау** (*3 мәгъ.*). *--- каладагы театр һәм кәмит төсле заманча эшләрдән яхшы хәбәрдарлыгы булган Корытай Хафиз, мәсьәләне тиз арада сәясәткә борып җибәреп, үзенә кирәкчә сүз туглату җаен бу очракта да тиз тапты ---.* Ф.Яхин

**Туглата башлау** Туглатырга тотыну

**Туглатып тору** Даими, һәрвакыт туглату

**ТУГЛА́У** *ф.* 1) Сыек яки бөртекле әйберләрне үзара катнаштырып, аралаштырып болгату. *Сыерына онын, көрпәсен бергә туглап, тозын да салып, бер чиләк витаминлы суын да әзерләде.* Г.Галиева. *Хатын күәс чиләгенең төбенә җылы су сала, ипи калагы дигән хикмәтле агач калак белән электән күәс төбендә калган ачы камырны туглап җанландыра.* М.Мәһдиев

2) Болгатып күпертү. *Һәр көнне, иртә торгач та, ач карыннан үзенә бер стакан сөткә ике күкәй туглап бир.* А.Расих. *Аннары кружкага өч йомырка сытып, --- бик ныклап туглады, тагын аңа ниндидер дарумы, нәрсәдер тамызды һәм Иреккә эчерде.* Ф.Садриев

3) *күч.* Бертуктаусыз, кайта-кайта берәр нәрсә турында сөйләү, телдән төшермәү. *Мисыр күгәрчене кебек гөрләп, Бәдәр балаларны янбакчага алып чыкты, һаман бер сүзне туглады.* А.Гыйләҗев. *Кайсысы гына экранга чыгып утырмасын, бер үк сүзне туглый: рубль ныгыды, диләр, экономика стабильләште, --- диләр.* Ф.Баттал

**Туглап алу** Тиз генә, кыска гына вакыт туглау. *Хатын-кыз, гомумән, озынозак итеп аңлашырга, тыныш билгеләрен урынына куеп, әхлакый оеткыны туглап алырга ярата.* Т.Галиуллин. *100 г туңдырмага 500 мл сөт салып тугларга һәм, шуңа ике банан пюресы кушкач, яңадан туглап алырга.* Ашыгыз тәмле булсын!

**Туглап бетерү** Туглауны тәмамлау; барысын да туглау

**Туглап җибәрү** Бераз, берникадәр туглау. *Онны, Алла боерса, менә ашка туглап җибәребез.* Т.Биктимирова

**Туглап карау** Нәрсәне дә булса эшләп булу-булмауны тикшерү-сынау өчен туглау

**Туглап кую** Тиз генә туглау яки алдан туглау; тугланган хәлгә китерү. *Камыр басу он белән суны туглап кую гына түгел шул.* Минем йорт

**Туглап ташлау** Тиз генә туглау. *Дөнья шулай ул: бер буталдыңмы, бөтенләй туглап ташлый, бәхетеңне кайда һәм кайчан югалтканыңны да онытасың!* М.Юныс

**Туглап тору** Бертуктаусыз туглау; хәзер, сөйләп торганда туглау. *Миңа бер карт солдат каушамау серен өйрәтте: син, диде, эчтән генә үзеңә «юк, каушамыйм, курыкмыйм» дип гел туглап тор!* Х.Камалов. *«Әлмәтем» дип туглап тормасам да, Мин яратам сине, Әлмәтем!* К.Булатова

**Туглый башлау** Тугларга тотыну. *– Хәзер коймак пешереп алырмын! – дип, әбисе камыр туглый башлады.* Р.Батулла. *Әни мичкә ягып җибәрде, бер савытка йомырка сытып, сөт салып, коймак туглый башлады.* Н.Әхмәдиев

**Туглый тору** Ниндидер бер вакыт арасында туглауны дәвам итү. *Шулай була бит ул: сөт өстен туглыйсың-туглыйсың, май төшми, аннары туглый торгач, болгаткыч белән, ничектер, бер китереп бәрсәң – сөт өсте куера да китә.* Сөембикә

**Туглый төшү** Бераз туглау; тагын да ныграк туглау

**ТУГРА** *и.* 1) Урта гасыр төрки дәүләтләрдә исеме символлаштырып бизәкләп язылган һәм имза буларак кулланылган хан мөһере. *Атилла ханның туграсы тигез чатлы тәре була ---.* М.Хәбибуллин. *Вокзал башында*

*солтан Габделхәмиднең туграсы (матур итеп язылган исеме) әле дә ялтырап ята.* Х.Миңнегулов

2) Аерым дәүләтнең, шәһәрнең һ.б.ш.ларның махсус билгесе, эмблемасы; герб. *Шунысы кызыклы: китапның тышлыгында Алтын Урда туграсы да төшерелгән.* Х.Миңнегулов. *Имеш, борынгы заманнарда аны дошманнардан аждаһа саклаган икән дә, хәзерге көндә дә бу шәһәрнең халкы, шул аждаһаның сурәтен ясап, аны тугралары урынына тоталар, ди.* Ф.Яхин

3) Аерым шәхес яки гаиләнең матур язылышлы исем-фамилиясе яки аларның баш хәрефләре; монограмма. *Сүз уңаеннан, ул бик күп дөньякүләм мәгълүм сәясәтчеләрнең үтенече буенча аларның туграларын иҗат иткән.* Казан утлары. *Күргәзмәгә чын сәнгать әсәре булырдай йөзләгән шамаил һәм шәхси тугра куелган.* Сабантуй

**ТУГРАЛЫ** *и.* Туграсы булган. *Гомер бакый яшәп һәм эшләп, үзен гәҗит-журнал битләрендә күрмәгән Мөнирә апагызның тулы исем-фамилиясе шома йөзле каты кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган, аллы-гөлле төсләр белән бизәлгән, тугралы тышлыкка кыстырылган.* К.Кәримов

**ТУГРАЧЫ** *и.* Тугра ясаучы, тугра остасы. *Танылган туграчы Нәҗип Нәккаш, шагыйрь туграсын ясап бүләк итеп, бу хәзинәне тагын да баетты.* Сабантуй

**ТУ́ГРИК** *и.* Монголия Халык Республикасында акча берәмлеге

**ТУГРЫ** I *и. бор.* Ау кошын кундырып йөртә торган агач; тургач, ту. *Тугрыңа кунган Төкле аяк Тугыз йортка дан булган.* Дастан

**ТУГРЫ** II *с.* **1.** 1) Ышанычлы, хыянәтсез, турылыклы. *Хуҗа белән тугры хезмәтче, әйткәнебезчә, бәйрәмнәр тирәсендә генә очрашалар, ешрак күрешергә ярамый.* А.Гыйләҗев. *Шулай итеп, тикшерү Муса Җәлилнең тугры дуслары һәм иптәшләре Шабаев белән Булатовның эзенә төшә.* Р.Мостафин

2) Дөрес, гадел. *Фикерең тугры, сүзең дөрес.* К.Насыйри. *Фатыйма апа кергәннән артык тугры сүзле иде.* Г.Гобәй. --- *ахырдан җинаятьчеләр, табылып, тугры хөкемгә тапшырылалар.* Татарстан яшьләре

3) Намуслы, вөҗданлы. *Сезнең тугры кеше булуыгыздан ышанам ки, сез гашыйк булгансыз, ләкин гашыйк булгансыз тышкы кыяфәтемә.* М.Акъегет. *Кем угры, кем тугры икәне хәзер беленер.* М.Фәйзи

4) *иск. к.* **туры**

**2.** *рәв. мәгъ.* Намус белән; хыянәтсез рәвештә; хыянәт итмичә. *Ләкин әнә шул куркуны җиңә алган, туган халкына, намуска тугры калган корыч ихтыярлы кешеләр бар.* А.Алиш. *Тик ул урыннан ераграк торырга кирәк дип, Әлфия вәгазь уку, акыл сату гадәтенә, старосталыгына тугры калып, нәтиҗә ясады ---.* Т.Галиуллин

**ТУГРЫДА** *бәйл. сүз иск. кит. к.* **турыда**. *Хәсән мулла һәр җомгада халыкны гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнәгать илә кызыктырыр; бу тугрыда Коръәннән һәм пәйгамбәремезнең тәрҗемәи хәленнән сөйләп, халыкка аңлатыр иде.* З.Һади

**ТУГРЫДАГЫ** *бәйл. сүз иск. кит. к.* **турыдагы**. *Аның бу тугрыдагы фикере хакында берничә сүз сөйләмәкче булабыз.* Ф.Әмирхан

**ТУГРЫДАН** *рәв. иск. к.* **турыдан**

**ТУГРЫДА́Н-ТУРЫ** *рәв. иск. кит.* **1.** *к.* **турыдан-туры**. *Фән хакыйкатьне тугрыдан-тугры, ягъни һичбер сурәткә кертмичә, хиссияткә кагылмыйча, хыялга манмыйча, үзен генә күргәзергә тырыша.* Җ.Вәлиди

**2.** *с. мәгъ.* Ачыктан-ачык әйтелгән. *Аңа тугрыдан-тугры сүз ачмый мөмкин түгел.* Г.Ибраһимов

**ТУГРЫЛАП** *рәв. иск. кит. к.* **турылап**. *Аучы --- бөркеткә тугрылап мылтык атты.* Г.Тукай

**ТУГРЫЛЫК** *и. кит.* 1) Дөреслек, чынлык

2) Гаделлек, хыянәтсезлек; берәр кешегә яки эшкә турылык. *Мине озатканда, ул: «Яшь лейтенантны җибәрербез. Армиягә тугрылыгын күрсәтсен әле», – диде.* Ф.Яруллин. *Алар өчен сугыш та, мәхәббәт, тугрылык дигән изге хис тә юк.* Н.Әхмәдиев

**ТУГРЫЛЫКЛЫ** *с. кит.* Хыянәтсез, намуслы; берәр кешегә яки эшкә чын күңелдән бирелгән. *Ул анда Туган илебезгә тугрылыклы булып тәрбияләнер.* М.Мәһдиев. *Тыштан барысы да Сөембикәгә гаять тугрылыклы булып йөриләр.* Х.Камалов

**ТУГРЫЛЫКСЫЗ** *с. кит.* Тугрылык сакламаган, сатлык, хаин. *Үзен бөтен нәрсәдән мәхрүм ителгән кебек тойды. Һаман бер кызык мәкаль исенә килә иде: ихтыярсыз ачу – тол, моңсуланусыз күңел – тол, тугрылыксыз сөю – тол, ирсез хатын – тол.* Х.Камалов. *Ник күтәрелеп караганына, ник туганына үкенде шул мизгелдә. --- Күзләрендәге тугрылыксыз караклык – бер хәл. Бәгыркәенең яңа тарттырган он кебек бөз күлмәгенең сул якасын --- куе кызыл иннек буявы бизи иде.* Т.Галиуллин

**ТУГРЫНДА** *бәйл. сүз иск. кит. к.* **турында**. *Табышмакларны да мәкальләр кебек мәҗүсият дәверенә һәм тормыш тугрында сөйләнгәннәргә аерырга мөмкиндер.* Ф.Сәйфи

**ТУГРЫСЫНДА** *бәйл. сүз иск. кит. к.* **турысында**. *Кияүгә чыгар алдыннан, әнкәем, киявем тугрысында бик күп сүзләр ишеттерделәр.* Г.Исхакый. *Теге көннәр хакында ачык бернәрсә сөйләмәгән кебек, алда ни эшләячәге тугрысында да билгеле бернәрсә әйтмәде.* Г.Ибраһимов

**ТУГРЫСЫНДАГЫ** *бәйл. сүз иск. кит. к.* **турысындагы**. *Думбралар моңына, Болгар белән Алмас хан тугрысындагы сүзләргә бәллүләнеп, арыган көйгә изрәп йокыга китәсең.* Ш.Әхмәдиев

**ТУГУ** I *ф. диал.* 1) *к.* **туглау** (*1 мәгъ.*). *Бер чиләк ашлык китереп, бозауларыма тугып бирдем.* Ә.Еники

2) Катнаштыру, кушу. *Героебыз рәтләп сөйли белми һич тә, Авыр сүзләрне әйтә алмый, читләп үтә, Җиңелләрен җырга тугып-тугып кертә.* З.Мансур

**ТУГУ** II *ф. диал. к.* **туку** I. *Чувашлар күлмәк вә ыштан кеби киемнәрне җитен, киндер сүсләреннән җеп эрләп үзләре тугыйлар.* З.Бәшири

**Тугып бетерү** Тугуны тәмамлау; барысын да тугу. *Мәрхүмнең башлаган чабаталарын да тугып бетерә алмаган бит [ул].* Г.Ибраһимов

**ТУГЫЗ** *сан* 1) Унарлы санау системасында 9 санын һәм цифрын, шул

сан исәбендәге микъдарны белдерә. *Ләкин бит инде Сталин үлгәнгә тугыз ел, XX съездда Сталинның шәхес культын тәнкыйть иткәнгә дә алты ел, нигә һаман шул хәл әле?* М.Мәһдиев. *Тугыз көн буе күңелдә хыялый бер уй йөрде: эх, өч-дүрт каекка җыелсын иде серләшерлек үзебезнең каләмдәш егетләр!* Р.Фәйзуллин

2) *күч.* Үзеннән соң килгән сүзләр белән күплекне белдерә. *Шәһәрнең буялган чәчле кыланчык кызларын бу кинога китереп утыртсаң, тугыз кат һуштан китеп егылыр иде.* Х.Туфан. *--- кояшта янып, битнең тиресе сыдырылып төште. --- Уйчанланып, сынга карап, озак утырды Рәшит. Шуннан әйтте: «Колларның тиресен тугыз тапкыр туныйлар, диләр. Ә миннән әле бер генә мәртәбә кубып төште».* З.Зәйнуллин

◊ **Тугызга бөгелү** 1) Кемгә дә булса нык ярарга тырышу, ялагайлану. *Ялтыравык төймәле чиновниклар, тугызга бөгелеп, сиңа баш ияләр.* Ш.Камал; 2) Бик түбәнчелек белән, зинһарлап үтенү, ялвару. **Тугызга туңкаю** *к.* **тугызга бөгелү**. **Тугыздан калган тукаби** Бертуган кардәшләре барысы да үлеп бетеп, бер ялгызы калган бала. **Тугыз төймә** *кимс.* Акылсыз кеше турында. *(Әнисе) тәрбияләп, өстеннән кош та очыртмыйча, өф-өф итеп өреп кенә, рәхмәт әйтә-әйтә, аркасыннан сөеп кенә яшәтер иде. Ә бу тугыз төймәдән – юк!* Г.Мөхәммәтшин

**ТУГЫЗАК** *и. диал.* 1) Ялгыз, бер генә, игезе булмаган терлек баласы, берләч

2) Төпчек бала; кинҗә

**ТУГЫЗАР** *сан* Һәркемгә яки һәрнәрсәгә бертигез күләмдәге тугыз булуны белдергән бүлү саны. *Балтач әтәчләре – талантлы халык, алар арасында җидешәр, сигезәр, хәтта тугызар бормалы итеп кычкыручы әтәчләр күп ---.* Р.Батулла. *Бераз баш-күз алгач, самолётларының эченә күз ташладым. Тугызар урынлы 17 рәтне санадым, калганнарын санап бетереп булмады.* Ф.Яруллин

**ТУГЫЗА́У** *сан* Барысы, бөтенесе бергә тугыз булуны белдергән җыю саны. *Өч бәйгедә җиңгән өчәр ат тугызау була, тугызавы да – баш биргәсез айгырлар.* Р.Батулла. *Мин, шарлар уйнаткан фокусчы кебек, шарларны бер кулдан икенчесенә күчерәм, һавага чөям – менә инде шарлар өчәү түгел, ә тугызау!* Х.Ширмән

**ТУГЫЗБУЫН** *и. бот.* Карабодайчалар семьялыгыннан тәлгәшсыман ал яки яшькелт ак чәчәкле, сабагы буынтыклы чүп үләне; тал үлән; *русчасы:* **гречишник шероховатый**

**ТУГЫЗКӨН** *и. бот. диал. к.* **татар зелпесе**

**ТУГЫЗЛАП** *сан* **1.** Чама белән тугыз, якынча тугыз булуны белдергән чама саны. *Ишегалдындагы тугызлап ояның тик дүрт-бишенә генә хуҗа табыла.* А.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тугызы бергә, тугызы берьюлы, тугызау булып, тугызы да. *Һәр рәткә тугызлап баскан солдатлар төркеме авыл урамын иңләп узды.* Яңарыш

**ТУГЫЗЛА́У** *ф.* Кайбер фразеологизмнар составында килеп, «дөрес булса-булмаса да, үз сүзен хаклы санап, шуны үткәрергә тырышу» мәгънәсен аңлата. *Председатель һаман үз тугызын ачыграк итеп тугызлады.* Г.Толымбай. *Артык үзсүзле кеше бит ул. Бер киреләнсә, үз тугызын тугызлый да тора.* К.Нәҗми

**ТУГЫЗЛАШЫП** *рәв. к.* **тугызлап 2.** *Сигезләшеп киттеләр, тугызлашып кайттылар*

**ТУГЫЗЛЫ** *с.* **1.** 1) Күләме, номеры, үлчәме тугыз булган. --- *күпме кеше чалгы тотып селтәнеп карады, кайбер егетләр, эх! дип, гайрәт тавышы белән җилпенеп тә карадылар. Әмма тугызлы чалгы дык итеп балчыкка төртелә, метрлы печән имгәнеп кенә кала иде.* М.Мәһдиев. *Гомәр оптик прибор аша башка мишеньне, аннары аның тугызлы һәм унлы түгәрәкләрен эзләп тапты.* Г.Рәхим

2) *күч.* Ярым-йорты, булыр-булмас, начар; төгәл, тулы түгел. *Минем русчам тугызлы гына*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тугыз санын белдергән цифр, тугызлык

2) Карта уенында: колоданың тугыз саны төшерелгән тугыз күзле картасы

3) Кискеченең үлчәме тугыз уч озынлыгына (90 см га) тигез булган чалгы. *Хәтерлим: безнең авылда тугызлы белән ике-өч кенә кеше эшли иде.* М.Мәһдиев

4) «Жигули» автомобиленең тугызынчы моделе. *Очып килгән тугызлы исә салулап алды, әмма тизлеген киметмәде.* М.Садыйков. *Бервакыт бер абый белән сәфәр йөргәндә, тәрәзәләре каралтылган тугызлы юлыбызга атылып чыкты.* Шәһри Казан

**ТУГЫЗЛЫК** *и.* **1.** 1) Тугыз цифры

2) *к.* **тугызлы 2.** (*2 мәгъ.*). *Тәре тугызлык*

3) *күч.* Акыл, аң, белем. *Икенче курска күчкән идем, тугызлык җитми башлады.* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ.* Тугызны күрсәтә торган, тугыздан торган, тугызга (сум, тиен) тигез булган. *Тугызлык акча булмый.* Әйтем

◊ **Тугызлыкны ваклау** *ирон.* Сөйләшкәндә, чит тел сүзләре кыстырып, ике телне дә бозып сөйләшүчегә ишарә. *(Ясәви) сөйләшкәндә, гел урысча гына сукалаган була, ә сүзләрне ватып-җимереп әйтүен хәтта мин дә сизеп торам. Андый кешене «тугызлык ваклый» диләр бездә.* Ш.Маннур. **Тугызлыкны вату** *к.* **тугызлыкны ваклау**. **Тугызлыкны ватып булмый** Юкка көчәнү, юк эш артыннан йөреп тә эш чыгара алмау. *– Нишләп йөрисең болар ишек төбендә? – Йөрим менә, тугызлыкны ватып булмый әле.* Н.Исәнбәт

**ТУГЫЗЫНЧЫ** *сан* Санаганда, урыны сигез белән ун арасында булуны белдергән тәртип саны. *Гомергә өченче урыннан төшкәне булмаган колхозны ит һәм сөт түләү буенча тугызынчы урынга төшердең.* В.Нуруллин. *Резедә, тугызынчы класста укуына карамастан, акылы белән бала гына әле.* Ф.Яруллин

◊ **Тугызынчы дулкын** 1) Давыл вакытында була торган иң көчле һәм хәтәр диңгез дулкыны (мифологиядә тугыз саны сакраль санала). *20 нче еллар башында татар совет әдәбиятына, поэзия диңгезенең тугызынчы дулкыны сыман ярсып, тынгысыз Такташ килеп кергән иде.* Х.Туфан; 2) Бик зур хәвеф яки берәр нәрсәнең иң көчле мизлеге символы. **Тугызынчы вал**

*к.* **тугызынчы дулкын**. **Тугызынчы типкен** *к.* **тугызынчы дулкын**

**ТУГЫЛМА** *с.* Катнаштырылган; тугланган, кушылган, болгатылган. *Тугылма сыеклык*

**ТУГЫЛУ** *ф. диал. к.* **тукылу**. *Яссы-яссы яфрак, Яткан җире туфрак, Алтын бауга тагылган, Көмеш белән тугылган.* Табышмак. *Быел тугылган (сөлгеләрем) ике очы атмаган Укалы кондыз(дай).* Җыр

**ТУГЫМ** *и.* 1) Тәгәрмәчнең агачтан яки башка материалдан ясалган кыршауланган өлеше. *Гафиятулла колхозга тугым бөгә, тимерчелектә чүкеч суга.* Ф.Хөсни. *Су башта алгы тәгәрмәчнең тугымына җитте, аннан соң тугымны да күмеп китте.* Н.Фәттах

2) Нинди дә булса җайланманың төрле кисәкләрен кыршаулап, беркетеп торган божрасыман өлеше. *Тугымнарына бизәкле утыргычлар эленгән таганда яшүсмерләр сәләнәләр.* К.Нәҗми

3) *диал. к.* **тукым** I (*1 мәгъ.*). *Ияр астына яңа тугым салу*

◊ **Тугым бөгү** Туңу, өшү, күшегү. *[Гәрәйгә] йоп-йомшак сары толып кидерделәр. «Ат адымы салкын эзләр, тугым бөгәрсең!» – дип, кат-кат әйтте Закир ага.* А.Гыйләҗев. **Тугым тарту** Агач тәгәрмәч ясау өчен тугым бөгү. *Такта яру, тугым тарту мастерскойлары оештырып җибәрербез.* Т.Гыйззәт

**ТУГЫМЛА́У** *ф.* Кигиләргә тугым кидерү; тугым тишекләренә тәгәрмәч тырнакларын (кигиләрен) кертү

**Тугымлап бетерү** Тугымлауны тәмамлау; барысын да тугымлау

**Тугымлап карау** Булу-булмауны тикшерү-сынау өчен тугымлау

**Тугымлап кую** Тиз генә тугымлау яки алдан тугымлау; тугымланган хәлгә китерү

**Тугымлап чыгу** Булган берсен тугымлау

**Тугымлый башлау** Тугымларга тотыну

**ТУГЫМЛЫ** *с.* Тугымы булган

**ТУГЫМЧЫ** *и.* Тугым бөгүче оста. *Урман ягыннан озын арбаларга имән бүрәнәләр төягән җиде-сигез тугымчы килеп чыкты.* Г.Бәширов. *Әйләнә-тирәдә дан тоткан балта остасы, --- беренче кул тугымчы [авырып ята].* Г.Ахунов

**ТУДЫЙ** *и. диал.* 1) Ике яшьтәш яки адаш килендәшләр бер-беренә якын итеп, иркәләп эндәшә торган сүз. *Фатыйма тудыйлар өе*

2) *к.* **тудыка** (*1 мәгъ.*). *Тудыйларга утырмага бару*

**ТУДЫК** *и.* 1) Кардәш хатыннарның бер-беренә якын итеп, иркәләп эндәшү сүзе. *Фатыйма тудыкның Ушабашы җыенына кайтканда онытып салып калдырган бөтилеген актарып, төргәк-төргәк чәчләр --- табып алганлыгын гаҗәп зур осталык белән сөйли.* М.Гали. *Минем тудыкларның балалары читтә туып үсте ---.* Сөембикә

2) *Җиңги, апа, тумачи* һ.б.ш. сүзләр алдыннан килеп, аларга иркәләү, ярату төсмере бирә. *Туганым җиңги, тудык апа, апак абыстайлар да сөенечле, шат.* Г.Газиз. *Менә ата, менә кыз! Әйтерсең тудык тумачи. Кияүгә бару турысында атасы белән киңәшә!* М.Фәйзи

**ТУДЫКА** *и. диал.* 1) Туганнан туган кардәш. *Чынлап та, күршедә Динәнең тудыка апасы тора икән.* Х.Камалов. *Туганлык терминнарыннан Г.Ибраһимов әсәрләрендә атай – әд. әти, ана-кай – әнкәй; әни, тудыка – туганнан туган; туташ, абзасы – абыйсы һ.б.ш. сүзләр актив кулланыла.* Т.Хәйретдинова

2) Ике яшьтәш яки адаш килендәшләрнең бер-беренә үзара эндәшү сүзе

**ТУДЫКАЙ** *и. ирк. диал.* 1) *к.* **тудыка**. *Чыбылдыгым чып-чыбар, тудыкайлар. Чебен кунгач, кем куар, тудыкайлар.* Җыр

2) Кардәш һәм яшьләре бер тирә хатын-кызларның үзара бер-беренә якын итеп, иркәләп әйтә торган сүзе. *Тәрәзә төпкә кош кунган, Ташлама, әти, таш белән, Үз тиңнәрем килеп җиткәч, Тудыкайлар, Озат, әни, аш белән.* Җыр. *Ярамас эш түгел бу, Хәдичә тудыкаем, бик ярый.* Э.Касыймов

**ТУДЫРТУ** *ф. йокл. юн. к.* **тудыру**. *Ходай Тәгалә тагы шундый шигырьләр тудыртсын, яздыртсын.* Н.Нәҗми. *Бала тудыртудан бүтәнне беләмени соң ул?* В.Нуруллин

**ТУДЫРУ** *ф.* 1) Балага тормыш бирү, баланы дөньяга китерү; бәбәй китерү, бәбәйләү. *– Күрдем мин ул колны, – дип җавап бирә карчык, – моңа кадәр әле минем бер генә хатынның да шундый сылу кыз тудырганын күргәнем юк иде.* Әкият. *Үзем өч бала тудырып, үземә ник берсе охшасын.* Г.Галиева

2) Берәр эш-хәлне, күренешне һ.б.ш.ны барлыкка китерү, китереп чыгару, шуларга сәбәп булу. *Андый чакта [бүреләр], беренче эшләре итеп, көтүне һәрьяклап чорнап алалар. Әле теге, әле бу яктан һөҗүм иткән булып, көтүдә паника тудыралар.* А.Хәсәнов. *Зилзилә --- чутына чыкмаслык мәшәкатьләр, бимаза тудыра.* Д.Гайнетдинова

3) Булдыру, тәэмин итү. *Ул чагында милли мәдәният һәр шәхескә рухи үсеш шарты тудыра.* Р.Сафин

4) *күч.* Иҗади эше белән берәр нәрсәне (мәс., рухи байлыкларны) барлыкка китерү; ярату. *Композитор көй тудырган ---.* Г.Афзал. *Күңел үзе бик җилкенә дә, җитди, йөрәк түреннән ташып чыккан әсәрләр тудырасы килә дә бит...* Г.Каюмов

5) *күч.* Берәр кешедә нинди дә булса сыйфатларны, үзлекләрне барлыкка китерү, формалаштыру, шул сыйфатларның барлыкка килүенә этәргеч, сәбәпче булу. *Габдулла абзыйны мин үзем тудырдым, үзем аңга керттем дип уйлый идем.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Нинди дә булса уй-фикер яки тойгы кузгату, ояту, шуларның килеп чыгуына сәбәп булу. *Дөрес җавап бирмәү аңарда үз-үзенә ачу тудырды ---.* Г.Кутуй. *Нинди генә булса да бер гаделлекнең тантана итүе Әнвәр күңелендә тере шатлык тудыра.* Х.Камалов

**Тудыра бару** Торган саен күбрәк тудыру. *Заман үзенең яңа йолаларын тудыра бара...* М.Мәһдиев

**Тудыра башлау** Тудырырга тотыну; тудыруга таба бару. *Бу миндә кимсенү хисе тудыра башлады.* Г.Бәширов. *Шул ач бүреләр булмагач, башка кошкортларны әйткән дә юк, хәтта мөгезбай пошилар да зәгыйфь, аңгыра балалар тудыра башлаганнар.* А.Хәсәнов

**Тудырып тору** Һәрвакыт, даими тудыру; бер-бер артлы тудыру. *Кайсы гына замананы алма, татар йортлары, татар авыллары, татар урамна-*

*ры, башка халыкныкыннан әйбәтрәк тә, төзек тә һәм күңеллерәк тә булып, йөрәкләрдә шатлык тудырып тора.* З.Зәйнуллин. *Улыңа шундый уңайлыклар тудырып торалар, ә син зарланып утырасың.* Җ.Дәрзаман

**ТУДЫРУЧЫ** *и.* 1) Баланы дөньяга китерүче, аңа тормыш бирүче. *Кешегә дөньяда өч кешедән котылу мөмкин түгел. Берсе – тудыручы. Теләсәң дә, теләмәсәң дә сине тудырмыйча калмый. Икенчесе – яучы...* Г.Бәширов. *Геяны греклар барлык кешеләрнең беренче тудыручысы һәм җир куенындагы мәетләрнең җыелу урыны дип исәпләгәннәр.* Н.Фәттах

2) *күч.* Берәр нәрсәне барлыкка китерүче; уйлап табучы, иҗат итүче, иҗатчы. *Шуны да уйлады: болар – намуслы, риясыз эшчеләр, матди байлык тудыручылар, андыйларга зур хөрмәт, кадер булырга тиеш.* Х.Камалов. *Әдәбиятта чын мәгънәсендә шигъри сүз әйтә алган шагыйрьләр шактый. Әмма алар арасында, башка жанрларны да бердәй якын күреп, игътибарга лаек әсәрләр тудыручылар бармак белән генә санарлык.* Л.Лерон

**ТУЕЗ** *и. диал.* 1) Туз, каен кайрысы. *Каеннан туез төшерү*

2) Тырыс. *Бер туез кура җиләге җыю*

**ТУЕМ** *с.* **1.** Бер мәртәбә ашап туярлык. *Бер туем ризык*

**2.** *и. мәгъ.* Ашау. – *Уенгамы, туемгамы? – Элек – уенга, аннан – туемга.* Такмак. *Уенга алданып, туемнан калма.* Мәкаль

**ТУЕМЛЫ** *с.* Туклыклы, калорияле. *Туемлы ашамлык*

**ТУЕМЛЫК** *с.* **1.** Туярлык, туйганчы ашарлык. *[Сый] туемлык түгел, күремлек.* Әйтем. *Бер стакан куаска ялландым, Туемлык микән, агакай?* Җыр

**2.** *и. мәгъ.* Туйганчы ашарлык ризык. *Туемлык бирәләр микән?*

**ТУЕМСЫЗ** *с.* 1) Туймас тамаклы, туймый торган, тамаксау

2) Комсыз, канәгатьсез, ачкүзле. *Сәнифәнең туемсыз комсызлыгы бар иде бит.* Х.Камалов. *Бәлки, туемсыз нәфесле хаким сыйныфларның байлык, җир-су бүлешүе аркасында торткынлыкта узган, җитәрлек сөя-сөелә алмый калган яшьлеген юксынуы булгандыр?* Т.Галиуллин

**ТУЕМСЫЗЛАНУ** *ф.* Комсызлану, ачкүзләнү

**Туемсызлана бару** Торган саен ныграк туемсызлану. *Беткәнче үзенеке генә булган яшь хатынның кайнар дәрте аны тарта кебек, әмма шул ук вакытта бу торган саен туемсызлана барган дәрт аны куркыта ---.* Ә.Еники

**Туемсызлана башлау** Туемсызлануга таба бару

**ТУЕМСЫЗЛЫК** *и.* 1) Туймас тамаклык, ашамсаклык; тамаксау булу. *Син кем әле сорау алырга, гаепләргә туемсызлыкта? Җыенмыйм да аны үтерергә, теләмим дә җаннар кыярга.* А.Нәҗми

2) Комсызлык, канәгатьсезлек, ачкүзлелек. *Комсызлыкның характерлы билгеләре – туемсызлык (моны ашауэчүгә генә кайтарып калдырырга ярамый, гомумән малга туемсызлык турында сүз бара), саранлык, көнчелек...* Ә.Еники. *Сезнең өчен, ахры, ашы кыйммәт, баштан ашканда да ил эше. Туемсызлык йоткач туганлыкны, ауган, әнә, Җучи олысы.* З.Мансуров

**ТУЕМСЫРА́У** *ф.* Туеп җитә язу, туя башлау

**ТУЕНДЫРГЫЧ** *и. тех.* **1.** 1) Машинаны май, су, ягулык һ.б.ш. белән туендыруны көйләү клапаны

2) *тех.* Ашлык, ком, вак ташлар ише бөртекле яки вак нәрсәләрне тегермәнгә, йөк машиналарына, станокларга һ.б.га селкеп яки транспортёрлар ярдәмендә бушата, агыза торган җайланма. *Барабанлы туендыргыч. Дисклы туендыргыч. Тасмалы туендыргыч*

**2.** *с. мәгъ.* Туендыру (*2 мәгъ.*) сыйфатына ия булган. *Хайван ашый алмаган очракта, туендыргыч сыекчалар, ә яшь хайваннарга тимерле дару матдәләре бирү каралган.* Агулы үсемлекләр

**ТУЕНДЫРУ** *ф.* 1) Ашату, азык бирү, тамагын туйдыру. *Менә шушы куллар бит инде безнең тормышыбызны алып бара, безне туендыра, киендерә.* М.Хәсәнов. *Орчык селкеп торган дирижёрлар түгел, бастырык белән эш иткән абзыйлар туендыра халыкны.* М.Маликова

2) Тук итү, тук хәлгә китерү, туйдыру. *Туендыра торган ризык*

3) Туфрак, һава, су һ.б.ш. белән тәэмин итү, биреп тору. *Ул бер үк төрле ике гөл алып, шуларның берсенә микродулкынлы мичтә җылытып суытылган су сипкән, ә икенчесен элек ничек гап-гади су белән туендырса, моннан соң да шулай эшләвен дәвам иткән.* Э.Фатыйхова. *Океан Җирдә табигатьнең бик күп сыйфатларын билгели: үзендә тупланган җылылыкны атмосферага бирә, аны дымга туендыра.* Материклар һәм океаннар географиясе

4) *тех.* Нормаль эшләтү өчен, электр тогы, ягулык һ.б. белән тәэмин итү. *Пар казанын су белән туендыру*

5) *хим.* Катнашмага берәр матдә, компонент өстәү, шунда эретү, катнашмада әлеге матдәнең концентрациясен арттыру. *Һаваны кислород белән туендыру. Эремәне тоз белән туендыру*

**Туендыра башлау** Туендырырга тотыну. *Кечкенә генә хатын үзенең үгез кебек таза һәм симез, ата мәче кебек ялкау ирен туендыра башлады.* М.Галәү. *Нәтиҗәдә ул берүзе эшләп, авыру ирен һәм университетта укучы улын туендыра башлый.* Э.Фатыйхова

**Туендыра төшү** Бераз туендыру

**Туендырып бетерү** Барысын да тулысынча туендыру. *Элек чәчелә торган җирләр генә бүредә яшәүчеләрне туендырып бетерә алмый.* Т.Нәҗмиев. *Без белгәннәре – халыкны диннән аеру; бөтен дөньяда коммунизм төзибез дип, үз халкыңның авызыннан өзеп, бөтен дөнья хәерчеләрен туендырып бетерергә омтылу; тузга язмаган, тормышка ашмастай хыяллар ---.* Р.Зарипов

**Туендырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә туендыру

**Туендырып карау** Туендырырга тырышу. *Шул кадәр тамакны туендырып кара әле!* Казан утлары

**Туендырып килү** Элек-электән, даими туендыру

**Туендырып тору** Һәрвакыт, даими туендыру. *Аның шикелле азык-төлек кибетендә эшләүче сатучылар үз тамакларын гына түгел, туган-тумачаларын туендырып торалар ---.* В.Нуруллин. *Ике чишмә урман кебек*

*куе әрәмәне суга туендырып тора.* Р.Батулла

**ТУЕНДЫРЫЛГАН** *с. хим.* Берәр матдәгә артык дәрәҗәдә бай булган. *Җылы суда тозны утырым барлыкка килгәнче эретергә кирәк. Утырым барлыкка килгәч, эремә туендырылган була.* Яшь натуралистларга. *Туендырылган эремәне суытканда, кристаллар хасил була.* Химия

**ТУЕНДЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **туендыру**. *Гаҗәп чиста, үтәкүренмәле, озон белән туендырылган җиләс, саф һава.* Т.Кәримов

**ТУЕНУ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса ашап тамак туйдыру, ачыгуны басу; туклану. *Үлән кыркып кына туенып барган колынкайлы бияне артык куып булмый шул, юлның соңгы яртысын туры бия гел үз көенә атлап кына барды.* Г.Галиев. *Кешеләр шуннан юа, кузгалак, сарана суганы, җиләк-җимеш җыйганнар, балык, камыш тамыры, акчарлак күкәйләре белән туенганнар ---.* Ф.Садриев

2) Үзенә берәр матдәне бик күп алу; эретү, сеңдерү. *Җир суга туенды, Басылды бер сусау.* Ә.Фәйзи. *Чишмә чыккан урында суга туенган соры ком шома ефәк тарттырып куйган кебек тип-тигез.* Г.Сабитов

3) Нормаль эшләү яки яшәү өчен кирәкле нәрсә белән тәэмин ителү. *Касыйм елгасының --- суы беркайчан да саекмый, чөнки елга төбеннән бәреп чыга торган күпсанлы чишмәләр белән туена.* Х.Садри

4) *күч.* Яшәү, тормыш итү өчен, үзенә тереклек чаралары табу. *Ярты авыл бездән туенып тора ич.* И.Гази. *Милли мәсьәлә бүген дә нәкъ Сталинча алып барыла, шул рәвешле дәвам итә. Шушы хәл аркасында политработникларның нәсел-нәсәбе туенып яши ---.* З.Зәйнуллин // Башкалар хисабына көн күрү. *Минем кул көчем аркасында күп капкорсаклар туенып ятты.* А.Алиш. *Күрә иде бит ул теге хатыннар өстендә туенып яткан студентларны, белә иде бит алардан яшьләрнең ничек көлгәнен!* М.Маликова

5) *күч.* Рухи, иҗади канәгатьлек алу. *[Шәкерт] хыял белән торырга вә фараз белән туенырга башлый.* Ф.Әмирхан. *Күп сөендем, сөенеч белән туенмадым, туймадым.* Ш.Бабич

6) *күч.* Гомумән канәгатьләнү, тую. *Нәфес тә түгел иде бугай, шуларны исән-сау гына сатса, акчага туенып кебек иде.* Н.Гыйматдинова

**Туена башлау** Туенуга таба бару. *Бәлки, безнең иң ерак бабаларыбыз әле үлән-тамыр җыеп туена башлаган чакларында ук бу үсемлекне өреп карарга, сызгыртырга өйрәнгәннәрдер.* Ә.Еники. *Ачлыктан котылып, бераз гына тернәкләнеп, ипигә туена башлаган гаиләгә тагын бәхетсезлек килә: әтиләре Ибраһим абый кинәт кенә үлеп китә.* Гасырлар авазы

**Туенып алу** Тиз-тиз генә туену. *Туенып алабыз да, зур кибән тирәли баш төртеп йоклыйбыз.* М.Кәрим

**Туенып бетү** Тулысынча туену. *Рәфис инде ашаудан туктаган, Шәмсуннең туенып беткәнен түземсезлек белән көтеп, әледән-әле тәрәзә ягына күз ташлаштыргалап утыра иде.* А.Вергазов

**Туенып җитү** Тиешле дәрәҗәдә туену. *Шул вакытта гына алсу чәчәк шифалы суларга туенып җитә.* Ф.Яруллин

**Туенып калу** Ниндидер сәбәптән соң туену; туенырга өлгерү. *Җир көздән үк суны үзенә сеңдереп, суга туенып калган.* А.Алиш. *Быел яз да игенчелек өчен бик уңай килде, чөнки явым-төшемнәр 50–70 мм булды, һәм туфрак көздән үк дымга туенып калды.* Ватаным Татарстан

**Туенып килү** Озак вакытлар дәвамында, даими туену. *Рус халкы ялкау, эчкече, ул гомере буена башка, кечерәк халыклар исәбенә, шуларны үзенә буйсындырып, шулар исәбенә туенып килгән.* Гасырлар авазы

**Туенып тору** Әле, хәзерге вакыта туену; даими, дәвамлы туену. *Ярлы солдат балалары алабута белән, кычыткан ашы белән туенып тора.* Г.Бәширов. *Сез бит, авылдашлар, гомер буе колхоз склады аркылы ашап яшәдегез, үзегез, балаларыгыз шушыннан туенып торды.* Х.Ибраһим

**Туенып яту** *сөйл. к.* **туенып тору**. Билгеле бер вакыт аралыгында туену; туену процессында булу. *Ул тау астына төшеп җиткәндә, нинди‌дер үләксә белән туенып яткан козгыннар, ямьсез каркылдап, дәррәү кузгалып киттеләр.* Х.Камалов

**ТУЖУ́РКА** *и. фр.* Ике капламалы, озын җиңле, якалы куртка. *Алардан соң җиз төймәле яшел тужурка кигән, чем кара чәчләрен сулдан уңга ерып тараган базык-таза гына бер студент егет чыгып җырлады.* Ә.Еники. *Озынчарак каратут йөзле, --- урта буйлы, өстенә нык кына кыршылган күн тужурка, башына кызыл тасмалы папаха кигән ул кеше иң беренче булып өйгә килеп керде ---.* В.Нуруллин

**ТУЗ** I *и.* **1.** Каен кайрысының өске катлавы. *Ул чыраларны, әрдәнәләрне үләнсезрәк җиргә салып, асларына туз тыкты һәм кабызып җибәрде.* Ф.Садриев. *Кара күннән, арты басылмасын өчен, эченә каен тузы куеп, әти тегеп бирде сандалины.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Каен кайрысыннан ясалган. *Үзең гөмбә икәнсең, туз чиләккә кер дә ят.* Мәкаль. *Кулына җиләк җыя торган туз савыт тоткан Сафура килеп керә.* А.Әхмәт. *Күбәләкләр, бербер артлы уянып, --- куаклардан чык бөртекләре җыеп, ап-ак туз тырыска тутыралар ---.* Г.Сабитов

◊ **Тузга язмаган** 1) Юк-бар, буш, мәгънәсез, тозсыз (сүз, фикер). *– Әллә нинди тузга язмаган сүзләргә өйрәнеп беттең әле син! – диде сүзен ярты юлда бүлдергән хуҗасы, кырт кисеп.* Ф.Баттал. *Тузга язмаган сүз сөйләп йөри торган сабый чагым үткән.* В.Имамов; 2) Кеше ышанмаслык, ялган, уйдырма (сүз, гайбәт һ.б.). *Җыен тузга язмаган уйдырмаларга, ялган күрсәтмәләргә генә таянып, кешене гаепли торган законны белмим мин.* М.Хәсәнов. *Каһәр төшкере, җыен тузга язмаган уй укымышлы кешеләр башына килә.* Ф.Яруллин

**ТУЗ** II *и. пол.* 1) Уртасына бер генә билге төшерелгән һәм иң зур очколы уен картасы. *Сәке өстендә, сәке астында, идәндә өер-өер булып утырган, яткан, аягүрә баскан, азарт белән шашкан төркемнәр. – Буби валет! – Банкта унбиш паёк. – Яп туз белән!* И.Салахов

2) *күч.* Берәр өлкәдә бик зур түрә; иң баш кеше. *Ул еллардагы концертларда Мөнирә Булатова, --- Гөлсем Сөләйманова һәм, әлбәттә инде, ике генә туз – Фәхри Насретдинов белән Усман Әлмиев җырлый иде.* М.Мәһдиев. *Аларның берсе завод директоры булып, икенчесе профсоюзда «туз» шикелле кыйланып утырса да, бүгенге кәнәфи, «Волга»лары өчен миңа бурычлылар.* В.Имамов

**ТУЗ** III *и. диал.* Шампиньонсыманнар семьялыгыннан кипкәч эче яшел яки кара коңгырт тузанга әйләнә торган шарсыман кечкенә базидиаль гөмбә; туз гөмбә, тузан гөмбәсе, куык гөмбә. *Туздырма тузны, колагың чукракланыр.* Ышану

**ТУЗАН** *и.* 1) Бик нык вакланып он, порошок хәленә килгән балчык, ком яки таш бөртекләре. *Эссе тузан өермәсе Рушадны чолгап алды, вак тузан колакларга, теш араларына тулды, күзгә керде.* М.Мәһдиев. --- *атлы арбалар артыннан күтәрелгән тузан өермәсе күренмәс булганчы, Сәмига, өзгәләнеп, юл буенда елап калды.* Р.Кәрами

2) Кар, су кебек нәрсәләрнең бик вак бөртекләре. *Тәгәрмәч астыннан пырылдаган кар тузаны, соңгы сәлам булып, Әлфиянең эзләренә ятты...* Н.Гыйматдинова. *Төтен эченә кергән кебек, болытлар эченә кергәндә генә, канатлары, түш йоннары дымланып ала, канат җилпенгән саен, як-якка су тузаны оча.* Г.Гыйльманов

3) *бот.* Чәчәк эчендә микроскопик вак бөртекчекләрдән гыйбарәт серкә. *[Умарта корты] бер чәчәктән икенчесенә куна-куна, чәчәк тузанына буялып бетә. Ул тузанны бер чәчәктән алып, икенчесенә калдырып китә.* А.Алиш. *Ак тешләренә кадәр сары чәчәк тузаны йокканын күреп, мин тагын елмаям.* М.Галиев

4) *күч.* Кер, пычрак. *Җыерчык та, тузан да юк минем гөл шикелле күңелемдә.* Ә.Еники

◊ **Тузан астында калу** Күптән булганлыктан, озак вакыт үткәнлектән онытылу. *Ул пыяла күз чынлап та шулай ГПУ кешесе булып, Сәүбан Бикчәнтәевнең, тузан астында калды, дип уйлап торганнары тузан астында калмаган булса, ә? Харисның хәтере әллә ни калын тузан астында калмаган.* А.Фәлах. **Тузан (бөртеге) кадәр (хәтле, чаклы) дә** Аз гына да, бөтенләй (берәр нәрсә булмау, табылмау, эшләнмәү тур.). *Күңелемнең саф чишмәсеннән агып чыкты ул. Анда тузан кадәр дә кер юк иде.* Г.Бәширов. *Бу хәлләрдән соң Иргалинең тузан бөртеге кадәр генә шик-шөбһәсе кинәт кенә таудай булып үсте дә китте.* М.Хәсәнов. **Тузан булып җилгә очу** *к.* **тузанга тузу**. *Тузан булып җилгә очты Татлы хыял, Һәм күңелне кабат сарды Кара уйлар.* Йолдыз. **Тузан булып тузу** *к.* **тузанга тузу**. **Тузанга болгану** *к.* **тузанга тузу**. **Тузанга очу** *к.* **тузанга тузу**. **Тузанга тузу** Вакыт үтү белән юкка чыгу, тормышка ашмау (өмет, план һ.б.ш. тур.). *Шулай да минем урман рәхәтләрем тузанга тузды, күңелемә Фәйзулла агай килеп утырды...* Ш.Камал. **Тузандайны тубалдай итү** Нәрсәне дә булса чамадан тыш күпертү, әһәмиятсез нәрсәне зур әһәмияткә ия итеп күрсәтү. *Ул бит кайчакта тузандайны тубалдай итеп күрергә ярата.* Н.Фәттах. **Тузан иләү** 1) Тузанлы юлдан озак бару, йөрү. *Шулай тузан иләп, бер шәһәргә барып керделәр.* Һ.Такташ. *Мин, шушы мизгелдә тузан иләп теркелдәгән сарыклар артыннан барган бала, әйткәнемчә, нииндидер алтынчы тойгы белән беренче тапкыр үземдә нииндидер илаһи көчкә ия булган пәйгамбәри җан барлыгын --- тоям.* А.Хәлим; 2) Юкбар белән файдасызга вакыт уздыру, мәгънәсез эш белән йөрү. **Тузан кою** Бераз вакытка эштән, көндәлек мәшәкатьләрдән арынып, онытылып тору. *Иртәгә Сабан туе якшәмбесе дигән көнне, хатынымны алып, тузан коеп кайту нияте белән, Арча ягына сәфәр киттек.* Ф.Хөсни. *Арслан бүген үзе дә, начальник икәнен онытып, тузан коеп алырга каршы килмәс иде. Ләкин аңардан читләшәләр, аның шешә белән дус булмавын белгән көннән бирле, компанияләренә алмыйлар.* Г.Ахунов. **Тузан туздырып** 1) Кәеф-сафа чигеп, шау-гөр килеп; 2) Бик тиз, җитез итеп. *Болдырда кара чәчен иңенә туздырып салган бер яшь хатын мандолина чиертеп утыра, шундый ук бөдрә чәченә кызыл бант бәйләгән кыз бала тузан туздырып биеп ята икән.* М.Маликова. **Тузаны гына калу** Бернәрсә дә калмау. *Ярый дәшми калды, денсез, юкса көя күбәләге урынына бармак арасында уа идем үзен, бары тузаны гына калыр иде.* А.Расих. *«Кырык капка» күптән совхоз үзәгенә кушылды. Монда аның тузаны гына калды, йортсыз нигезләр, урамында бала-чага авазы да яңгырамый ---.* К.Кәримов. **Тузаны да булмау** Аз гына да булмау, бөтенләй булмау. *Минем күңелемдә үчләшү дигән нәрсәнең тузаны да булмас.* Г.Бәширов. **Тузаны да калмау** *к.* **тузаны да булмау**. *Ул өч көн эчендә сиңа дигән икмәкләрнең тузаны да калмаячак.* Т.Гыйззәт. **Тузаны очу** Тар-мар ителү, көле күккә очу, тәмам юк ителү. **Тузанын кагу** 1) Кемне дә җиңелчә генә кыйнап алу. *[Хафиза:] Әллә нинди сугыш-фәләннәр булмагандыр бит? [Хафиз:] Юк, --- бераз гына, өстебездәге тузаннарны кагышкалап кына алдык.* Г.Камал; 2) Тәнкыйтьләү. *Туркаев безнең полкның да тузанын какты.* Ә.Маликов; 3) Бераз селкенеп, хәрәкәтләнеп алу (бию яки эш тур.). *Ягез әле, бер биеп алыйк. --- Әйдә, тузаннарыңны кагып ал.* М.Фәйзи; 4) Типтерү, кәеф-сафа кору. **Тузанын очыру** *к.* **тузанын туздыру**. *– Халыкка бер талпынып кузгалырга гына кирәк, – диде теге доцент. – Ул кузгалса, барысының да тузанын очырачак! Әнә немчураны Мәскәү тирәсеннән өч-дүрт йөз чакрымга куганнар бит!* Х.Камалов. **Тузанын селкетү** *к.* **тузанын кагу**. **Тузанын туздыру** 1) Бик нык ачулану, тиргәү, тетмәне тетү. *Миңа хәзер өйдән чыгу бетте инде, бүген әби барыбызның тузанын туздырды.* Ф.Сәйфи-Казанлы; 2) Бик нык кыйнау, тар-мар итү (дошман тур.). *Дошман кача! Ә без, куып җитеп, Туздырабыз аның тузанын!* Ш.Маннур

**ТУЗА́Н ГӨМБӘСЕ** *и. к.* **туз** III

**ТУЗА́Н ИТҮ** *ф.* 1) Тузанга әйләндерү. *Комны тузан итү*

2) *күч.* Тәмам юк иткәнче вату, җимерү; юк итү. *Алар кешене аяк астындагы тузан итәргә яратса да,*

*елакларга җирәнеп карый.* Г.Әпсәләмов. *Ахыр чиктә алар үзләре үк месркенлек чоңгылына тәгәрәде. Дөнья каршыларына башта алтын таулар өйде, аннары ишеп, тузан итте.* Н.Гыйматдинова

**ТУЗАНЛАГЫЧ** *и. тех.* Агулы, тузан хәлендәге коры химикатларны сиптерү аппараты; *русчасы*: **опыливатель**. *Тагылма тузанлагыч. Моторлы тузанлагыч*

**ТУЗАНЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Тузан туздыру, тузанга буяу, тузан утырту

2) Корткычларны яки авыру таратучыларны бетерү өчен, үсемлекләргә агулы матдә сиптерү. *Коңгызлар зарарлаган каен җиләген ДДТ дусты белән тузанландыралар.* Йорт эшләре. *Шушы катнашманы марлядан ике катлап тегелгән капчыкка салырга һәм үсемлекләрне шуның белән тузанландырырга кирәк.* Минем йорт

3) *бот.* Үсемлектә серкәне аналык органына (җимешлеккә) күчерү

**Тузанландыра башлау** Тузанландырырга тотыну

**Тузанландырып бетерү** Бик нык тузанландыру

**Тузанландырып тору** Бертуктаусыз, гел тузанландыру

**ТУЗАНЛАНУ** *ф.* 1) Тузанга буялу, өстенә тузан утыру, тузан белән каплану. *Бик яңадан булмаса да пинжәк, чалбар, аякта ботинка, тик арбада кырык чакрым килеп, алар шактый таушалган һәм тузанланган иде.* Ә.Еники. *– Танырлык та түгел үзеңне, – ди Нәзир, кызның каралган, тузанланган йөзенә карап.* Ф.Яруллин

2) Тузан чыгару, тузан туздыру. *Котырган каты өермә җенләнеп, тузанланып килә дә карт агачны уратып ала.* Г.Ибраһимов. *Исәр-исмәс җил белән әкрен генә тузанланып, тынгысызланып торган юл --- [тынлыкны] боза алмый.* Ә.Фәйзи

3) *бот.* Үсемлектә аналык органына (җимешлеккә) серкә күчү

**Тузанлана бару** Акрынлап тузанлану, торган саен ныграк тузанлану

**Тузанлана башлау** Тузанланырга тотыну

**Тузанлана төшү** Беркадәр тузанлану

**Тузанланып бетү** Тәмам тузанлану. *Сынчының өендә робот түгел, гадирәк автоматлар да юк, хәтта тузанланып беткән телевизоры да әллә кайчан искергән һәм картайган модель иде.* А.Тимергалин. *Тузанланып беткән, бәясе төшерелгән күн бүрек әле җиләгеннән бер тиен табыш тапмаган абзыйның башына инде менеп утыра ---.* М.Мәһдиев

**Тузанланып тору** Әле, хәзерге вакытта тузанлану; һәрвакыт, гел тузанлану

**Тузанланып яту** *сөйл.* Озак вакытлардан бирле тузанлану. *Мисал итеп ул өстәл тартмасында аунап, тузанланып яткан юлбашчы рәсемен --- чыгарып куйды.* Х.Ибраһим

**ТУЗАНЛАТУ** *ф.* Тузанга буяу. *Урам башына җыелып торган дус-ишләремне күреп кабаланып киттемме, көтмәгәндә, шул каралы-кызыллы башмакларымны тузанлатып, --- яңгырдан соң чокырланыбрак калган җиргә барып төштем.* Казан утлары

**Тузанлатып бетерү** Тәмам тузанлату

**ТУЗАНЛА́У** *ф. к.* **тузанландыру** (*1 мәгъ.*). *Мәдрәсәнең почмакларына юеш тәрәзә төпләреннән су ага, кемдер коридорда, бик тузанлап, киез кага иде.* Г.Ибраһимов. *Икенче көнне барыбер яңгыр килде. --- Бүгенгесен юып төшереп, иртәгәсен тагын да чистарак, яктырак итәр өчен, янып көйгәннәргә җан өрү, кызып тузанлап баручыларны туктатып уйландырыр өчен.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Тузанлап бетерү** Бик нык тузанлау

**Тузанлап тору** Бертуктаусыз, гел тузанлау

**Тузанлый башлау** Тузанларга тотыну

**ТУЗАНЛЫ** *с.* Тузанланган, тузан каплаган, утырган. *Оекбашлар, кызыллызәңгәрле яулык-кыйгачлар, бармакчалары ләпшердек пирчәткәләр, тузанлы киштәләрдә озак аунап төс җуйган чүпрәк-чапрак рәтендә дә озак юанмады.* А.Гыйләҗев. *Егетләр тузанлы киң юлның як-ягына таралдылар да сүзсез генә кузгалып киттеләр.* Н.Фәттах

**ТУЗАНЛЫ КИСӘ́Ү** *и. бот.* Бөртекле культураларда зарарлы кара спораләр үрчүгә китерә торган гөмбә авыруы

**ТУЗАНЛЫЛЫК** *и.* Тузанлы булу. *Бу курчак бүлмәгә аяк басуым белән үк өстемдәге киемнең керлелеген, аягымдагы итегемнең тузанлылыгын сизеп алдым.* А.Шамов. *Ул «Мәктәп бүлмәләренең тузанлылыгы һәм микроорганизмнар белән пычрануы» дигән темага чыгыш әзерләде.* Яңа тормыш

**ТУЗА́НСУЫРТКЫЧ** *и.* Әйбер өстеннән көчле һава агымы ярдәмендә тузанны суыртып ала торган көнкүреш электр приборы. *Җәй буе тузан йотып, билен дә турайта алмый буразнага башын органнарга тузансуырткыч булса да бирми кара, сыер саварга бармый башларлар.* Н.Хәсәнов. *Кире үз бүлмәсенә күтәрелгәндә, анда тузансуырткыч жуылдый, ике яшь кенә кыз чүпрәкләр тотып мәш киләләр иде.* К.Кара

**ТУЗА́Н-ТУФРАК** *җый. и.* Тузан катыш туфрак. *Бераздан, тирән чокырга тәгәрәп, терелә алмаслык булып имгәнгән һәм тузан-туфрак белән күмелгән.* Г.Гыйльманов. *Ә мүкләнгән Таш исә коры җирдә, эссе кояш астында, тау башында ялгызы ята-ята тәмам тузган, тузан-туфракка әйләнгән.* Р.Мулланурова

**ТУЗАНЧА** *и.* Күбәләк канатындагы төрле төстәге пигментлы катламны хасил иткән тәңкәчекләрнең берсе. *Ул нурлар баланың ак чыраен нәкъ менә күбәләк канатыннан бармакка ягылып кала торган алтын тузанча кебек алсу төскә манган.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Күбәләкнең төрле төстәге тузанча белән капланган икешәр зур канаты бар.* Зоология

**ТУЗБАШ** *и. зоол.* Сулык яннарында яши, бакалар белән туклана торган, баш артында ике саргылт табы булган карасу соры төстәге агусыз елан; *русчасы:* **уж**. *Алып хәтле гәүдәң белән нигә ул кеп-кечкенә тузбашларны үтерәсең?* Р.Батулла. *Еланнарның бу төре – тузбашлар – гомумән, каралты-кура, йорт, ихата, кешеләр ышыгына тартылалар, дип ишеткән бар.* А.Хәсәнов

**ТУЗБА́Ш ЕЛАН** *и. зоол. к.* **тузбаш**. *Алар анда коенганда, бер заман бер тузбаш елан яр астыннан килеп чыккан да Маһишәкәрнең күлмәге эченә кереп яткан.* М.Сабиров. *Бер генә тузбаш еланның да бер генә кешегә дә зыян-*

*зәүрәт ясаганы, бәла-каза китергәне юк, дип тәгаен әйтә алабыз.* Н.Сәйяр

**ТУЗБАШЛЫ́ ЕЛАН** *и. зоол. к.* **тузбаш**. *Кара да елан, ай, тузбашлы. Йөзәдер лә камыш буенча.* Җыр. *Тузбашлы елан чакмый ул.* Г.Галиев

**ТУЗГАК** *с.* **1.** 1) Тузгыган, чуалган; күпереп, төрле якка тырпаеп торган. *Ул көрәнсу битле, уртача буйлы, йомры гына гәүдәле. --- Көрән тузгак чәчләрен ак берет җыеп тора.* Х.Камалов. *Фронтта югалган тузгак яллы айгырлар, бүрек кадәр бәкәлле бияләр урынына --- яңалары үсә торды.* А.Хәсәнов

2) *диал.* Тузган, җыелмаган. *Тузгак бүлмә*

3) *диал.* Пыскып ява торган, бик вак. *Пыскак яңгыр*

**2.** *и. мәгъ.* 1) *бот.* Гадәттә карт каен, зирек, миләш һ.б. агачларда паразит булып үсә торган ашарга яраксыз зур башлы гөмбә, агач гөмбәсе, каты гөмбә, ку гөмбәсе; *русчасы:* **трутовик**. *Ике тузгактан һәм кипшерә башлаган бер-ике бөрлегәннән башка берни дә тапмадык.* А.Гыйләҗев. *Ашказанында сок бүленеп чыгу кимеп, гастрит авыруы күзәтелсә, ку гөмбәсен (тузгакны) кулланалар.* Сәламәт яшәү нигезләре

2) *диал.* Вак яңгыр. *Тузгак сибәләү*

**ТУЗГАКБАШ** *и. бот.* 1) *сөйл. к.* **тузганак**. *[Кызчык] тузгакбаш өзеп алды, --- кулындагы шушы ап-ак күперенке йомгакка карап торды. Өф итеп өреп куйды. Тузгакбашның җилдәй җиңел мамык җепселләре бөтерелеп очып китте.* Р.Төхфәтуллин

2) Җикән

**ТУЗГАКЛАНУ** *ф.* Тәртипсез чуалу, тузгу, төрле якка тырпаю. *Айгырның ялы тузгакланган*

**Тузгаклана төшү** Бераз, беркадәр тузгаклану

**Тузгакланып бетү** Бөтенләй тузгаклану

**Тузгакланып тору** Әле, хәзерге вакытта тузгакланган булу; һәрвакыт, гел тузгаклану

**ТУЗГАКЛЫК** *и.* Тузгак булу

**ТУЗГАЛАК** *с. сөйл. к.* **тузгак** (*1 мәгъ.*)

◊ **Тузгалак баш** *к.* **тузгый баш**. *Бичара картның күңелгә вәсвәсә салучы теге тузгалак баш алдында шулай да бер өстенлеге бар.* Ф.Хөсни

**ТУЗГАЛАНУ** *ф.* 1) *к.* **тузгаклану**. *[Бибизәйниянең] яулыгы бер якка китеп, чәче тузгаланган.* Г.Ибраһимов

2) Нык тузу, таушалып эштән чыгу, теткәләнү

**Тузгалана төшү** *к.* **тузгаклана төшү**

**Тузгаланып бетү** *к.* **тузгакланып бетү**

**Тузгаланып тору** *к.* **тузгакланып тору**

**ТУЗГАНАК** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле, түптүгәрәк башындагы мамыксыман төкле орлыклары аз гына җил исүгә очып китә торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **одуванчик**. *Бакчабызда, урман аланында я болын түрендә барыбызга яхшы таныш гап-гади тузганак үсеп утыра.* А.Хәсәнов. *Эһ дигәнче, минем башым мамыгын җил очырып шәрәләндергән тузганакка охшап калды.* Ф.Яруллин

**ТУЗГАНЛЫК** *и.* Тузу дәрәҗәсе, искергәнлек. *Элек Гөлшәһидә ничектер күреп бетерми идеме, больница аңа ярыйсы төзек булып тоела торган иде. Җентекләп карый башлагач, --- тузганлык күзгә ташланды.* Г.Әпсәләмов. *Палаталардагы искелек, тузганлык нык күзгә бәрелде.* М.Маликова

**ТУ́З ГӨМБӘ** *и. к.* **туз** III

**ТУЗГУ** *ф.* 1) Төрле якка тәртипсез рәвештә чуалып таралу (чәч, йон, мамык һ.б.ш. тур.). *[Аның] кыска соры чәчләре, тузгып, маңгаена сибелә.* Г.Әпсәләмов

2) Бөркелү, очу, һавага күтәрелү, тәртипсез рәвештә таралу. *Көн кояшлы, --- кыек читләрендә беренче тамчылардан сузылган бармак буйлык кына «сөңгеләр» җемелди, кайбер морҗалардан төтен тузгый ---.* Ә.Еники. *Капкалар шыгырдады, келәтләрдә он тузгыды, морҗадан төтеннәр үрләде.* М.Мәһдиев. *Урамда куе сыкы катнаш кар бураны тузгый.* М.Хәсәнов

3) Әйбернең тәртибе бозылу, таралу, пыран-заран килү. *[Илсөяр] атлы казаклардан тузгып калган өйне җыештырырга тотынды.* Г.Гобәй

4) Оешкан бер төркем таркалу. --- *Көтү тузгыган: сыерлар мөгриләр, атлар кешниләр, барысы да койрыкларын чәнчеп чабып йөриләр.* А.Алиш. *Бервакыт боларның умарталыгында кортлар тузгый, бер күч аерылып чыга.* Ватаным Татарстан

5) *күч.* Сибелү, таралышу. *Өйгә килеп кергәндә, мәҗлес тузгыган [иде инде].* Ф.Хөсни

6) *күч.* Тар-мар ителү, җимерелү, таралу, таркалу, юкка чыгу. *Карлыгач оясын туздырырга ярамый, йорт-җирең тузгыр.* Ырым. *Ул карга оясы күптән тузгыды бит инде.* Г.Бәширов

7) *күч.* Бик каты ачулану, кызып китү. *– Тагы шул гына җитмәгән, – диде кыз, шактый дорфа итеп. Нургали, аптырап, кызга текәлде: кара, кара, нигә әле бу үзе болай тузгый?* Ә.Еники. *Теге чакта керәшеннәрнең килеп чыгышы турында тузга язмаган сүзләр сөйләвем өчен, сиңа ачуланган булып тузгып йөрүләрем өчен үпкәләмә.* Г.Рәхим

**Тузгый башлау** Тузгырга тотыну. *Тегесенең күтәрелеп бәрелергә, ачуланып тузгый башларга атлыгып тормавын күргәч, тагын да кыюлана төште.* М.Хәсәнов. *Шуңа күрә аз гына җил чыгып алса да, монда ком бураны тузгый башлый.* Р.Мөхәммәдиев

**Тузгый төшү** Беркадәр, бераз тузгу; тагын да нык тузгу. *Миңә ул утырган җиреннән генә, киерелеп, ике кулы белән тузгый төшкән чәчләрен рәтләргә тотынды.* Ә.Еники. *Бераз тузгый төшеп, ак халатының чабуларын очындырып йөрергә яраткан шаян Газинур --- карап тора.* Г.Әпсәләмов

**Тузгып алу** Бераз гына тузгу. *Ап-ак тунлы бер көтү куян күренүгә, хәтта бераз буран тузгып алган.* Ф.Яруллин

**Тузгып бетү** Тәмам тузгу. *Һаҗәр аңа чынаяк белән су илтә, ләкин аның симез, ярым ялангач тәненә, чытылган йөзенә, тузгып беткән чәченә карамас өчен, читкә борыла.* Н.Әхмәдиев. *Халык үзен-үзе белештермичә кул чапканда, Хәкимҗанның каушаудан теле тотлыккан, --- Мостафаның чәчләре тузгып беткән һәм юеш маңгаена ябышкан иде.* М.Мәһдиев

**Тузгып калу** Берәр сәбәптән тузгыган хәлгә килү. *Элек бу өч-дүрт мәхәлләле бер авыл булган булырга тиеш.*

*Хәзер исә, өстеннән давыл узгандай, ул бик сирәкләнеп, тузгып калган иде.* Ә.Еники. *Таланган умарта кебек бөтен йортыбыз мыжгып, тузгып калды.* Ф.Яруллин

**Тузгып китү** Кинәттән тузгый башлау. *Шул ук вакытта җен карты шикелле үзсүзле, юк кына нәрсәдән дә үпкәләп, тузгып китә торган кеше иде.* Г.Рәхим. *Сары, хәтта бераз кызгылтрак бөдрә чәчләре тузгып киткән, костюмының чалгыен җыеп алуы була, август җиле --- аны яңадан ачып җибәрә.* Д.Бүләков

**Тузгып тору** Әле, хәзерге вакытта тузгыган булу; һәрвакыт, гел тузгу. *Тузгып торган чәченә дә бәс кунган.* М.Хәсәнов. *Әнә терекөмештәй бу егет аргамакта чабып килде дә яллары тузгып торган ат башы өстендә кылыч уйнатып алды ---.* Ф.Баттал

**ТУЗГЫЙ** *с. диал. к.* **тузгак** (*1 мәгъ.*). *Аның маңгаена таралып төшкән тузгый чәче, --- колак төбендәге яра эзе миңа ап-ачык булып күренә башлады.* Ф.Хөсни

◊ **Тузгый баш** *сөйл.* Чәче тузгып, таралып торган кеше. *[Егетнең] күзләре тагы әлеге --- баскычта шаккатып калган тузгый башка төште.* Ф.Хөсни

**ТУЗГЫЛДÁУ** *ф.* Тузгу, таралу, пумалаланып тору

**Тузгылдап тору** Әле, хәзерге вакытта тузгылдаган булу; һәрвакыт, гел тузгылдау

**ТУЗГЫЛУ** *ф. диал. төш. юн. к.* **тузгу**. *Офык буйлап килгән аккошлардай, Агылалар [болытлар] сузылып Һәм тауларга барып сарылалар, Чал чәчләр күк булып тузгылып.* Ш.Маннур. *Куе яфраклы Бөдрәләрең дә Тәмам тузгылып яталар җирдә.* З.Мансур

**Тузгыла башлау** Тузгылырга тотыну. *Ораторның тузган чәче трибуна өстендә җил белән тузгыла башлауга, татарлардан текстильче Галимов каты кул чабып җибәрде.* Г.Ибраһимов

**Тузгылып тору** Әле, хәзерге вакытта тузгылган булу; һәрвакыт, гел тузгылу. *Рөстәмнең тузгылып торган кара чәчләре, туры очы аз гына түбәнгә табан бөгелеп торган борыны, зур кара күзләре күпләрне үзенә тарта.* Һ.Такташ

**ТУЗГЫН** *с.* Тузгый торган, тузгып тора торган

**ТУЗГЫНЛЫК** *и.* 1) Тузгып тору

2) *диал.* Тәртипсез таралу, таркаулык. *Мохтарның күз алдына --- тузгынлыкка йөз тоткан сугыш фронтыннан кайта торган ачулы, ач, йолкыш солдатлар [килде].* Ш.Камал

**ТУЗГЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **тузгу** (*1–2 мәгъ.*). *Бик вак бөдрәләнеп, тузгынып, күперенеп, иңнәренә генә җитеп тора торган кыска гына кап-кара чәчле 17–18 яшьлек кыз бакча читәне янына килде.* Ф.Әмирхан. *Тол хатын авырый үзе дә бик каты, Тузгынып өелеп ята бар эшләре.* Аң

2) *күч.* Ыгы-зыгы килү, кычкырышу, талашу. *Бүлмәдә мәхшәр: кабаланалар, ай-һайлыйлар, тузгыналар.* Э.Касыймов

3) *күч. к.* **тузыну** (*3 мәгъ.*). *Күңелендә аңлатуы читен моң-зар кузгату өчен җитә калды шушы сүз, Иргали урыныннан ук сикереп торды. Хәтта тузгынып, әрле-бирле йөренеп тә килде.* М.Хәсәнов

**Тузгына башлау** Тузгынырга тотыну

**Тузгынып алу** Бераз гына тузгыну. *Әни, юеш киемнәрне күреп, тузгынып алды*

**Тузгынып китү** Кинәт тузгына башлау

**Тузгынып тору** Хәзерге вакытта тузгынган хәлдә булу; һәрвакыт, гел тузгыну

**ТУЗГЫТКЫЧ** *и.* **1.** Нәрсәне дә булса чәчтереп, таратып җибәрү өчен көйләнгән җайланма. *Печән күбәләрен тузгыткыч белән күтәртеп җибәрсәң, тизрәк кибәрләр иде.* Яңарыш

**2.** *с. мәгъ.* Тузгытып җибәрә торган. *Тузгыткыч җил*

**ТУЗГЫТУ** *ф.* 1) Бергә тупланган, җыелган, берегеп, өелеп, укмашып торган нәрсәләрне тәртипсез рәвештә төрле якка тарату, чәчү. *Саламны чанага салуың була, шуны гына көтеп торган җил аны тузгытырга тотына.* Н.Әхмәдиев. *Хантимер кызарып янган күмер өемен таягы белән бутап тузгытты да өстенә кочагы белән чыбык-чабык томырды.* Н.Гыйматдинова

2) Җилфердәтү. *Ә аннары ялларын тузгытып чапкан партизан атлары, базлы-чокырлы юллар, кара урман.* Г.Әпсәләмов

3) Сүтү, чуалту, билгеле бер тәртиптә торган нәрсәләрнең тәртибен бозу, таркату; тарату, таркату, сибү, чуалту. *Саллар тузгытып, урланган бүрәнәләрдән буралар бурап сатучы Мортаза атлы бер адәми затны ике-өч тапкыр тотып җавапка тарттырган.* М.Хәсәнов. *Авылда без кермәгән кыяр түтәле, без тузгытмаган карга оясы, без төшмәгән кар базы юк иде!* Р.Вәлиев

4) *күч.* Куып тарату; тар-мар итү. *Ул Иванның күпләгән кара явына каршы тора, гаскәрен тузгытып, чигенергә мәҗбүр итә.* Р.Батулла. *Заманында җиңелгән халыкның бар байлыгын талап алганнар, илләрен җимереп тузгытканнар, яндырганнар, изге җирләрен мәсхәрәләгәннәр.* Р.Фәйзуллин

**Тузгыта бару** Тагын да ныграк тузгыту

**Тузгыта башлау** Тузгытырга тотыну. --- *Җир астыннан янар таудай ут фонтаны бәреп чыкты. Каты җил, аның очкыннарын йолкып алып, әйләнәтирәгә тузгыта башлады.* С.Сабиров. *Чама белән үлчәгәндәй, көрт эченә керде дә аяклары белән карны як-якка тузгыта башлады.* М.Хәсәнов

**Тузгыта бирү** Бернәрсәне игътибарга алмыйча тузгытуын дәвам итү

**Тузгыта төшү** Бераз, беркадәр тузгыту; тагын да ныграк тузгыту

**Тузгытып алу** Бераз гына тузгыту. *Ул --- чәчләрен тиз генә киптерергә теләгәндәй тузгытып алды да янә җыеп артка сыпырды.* Н.Хәсәнов. *Җил уйнаклап йөри дә, барып бәрелергә урын тапмагач, пыялага сыланып, ыңгырашып куя. Сылу каеннарның бөдрә чәчен тузгытып ала ---.* А.Мансуров

**Тузгытып ату** *к.* **тузгытып ташлау**. *Алар берничә йортны җимергәннәр, ферманы тузгытып атканнар.* Татарстан яшьләре. *И.Гафуров университетның әле бер структурасына килеп бәрелә, әле икенчесен тузгытып ата.* Кәеф ничек?

**Тузгытып бетерү** Тәмам, бик нык тузгыту. *Үзе --- чабулап барышлый, өстендәге күлмәгенең якаларын, җиң очларын умыргалап атты, чәч толым-*

*нарын тузгытып бетерде.* В.Имамов. *Фәридә, бераз икеләнеп торганнан соң: – Җил чәчемне дә тузгытып бетерде, – дип җавап бирде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Тузгытып җибәрү** Тиз арада яки кинәттән тузгыту. *[Ул] чәчләрен бармаклары белән тагын да бераз кабартып һәм тузгытып җибәрде.* Ф.Әмирхан. *Рәмзия башын горур гына артка чөеп, төлке койрыгыдай чәчләрен тузгытып җибәрә.* Ф.Яруллин

**Тузгытып карау** Тузгытырга тырышу

**Тузгытып кую** Алдан тузгыту. *Ул башкаларга караганда чибәррәк, төз борынлы, зәңгәр күзле иде. Саргылт чәчләрен юри тузгытып куйган.* Казан утлары

**Тузгытып ташлау** Тиз, кисәк, бөтенләй тузгыту. *Әйтерсең аның мең йозак белән бикләнгән күңеленә ачкыч ясатып керделәр дә таслап-таслап куйган хисләрен тузгытып ташладылар.* Н.Гыйматдинова. *Казан тагын тузгытып ташланган кырмыска оясын хәтерләтә башлый.* И.Хуҗин

**Тузгытып тору** Һәрвакыт, гел тузгыту. *Бу – көн дә күренә торган каурый болытка охшамаган. Күз алдында ургыла, бөтерелә, кайный башлады, әйтерсең лә кемдер тузгытып тора.* М.Әмирханов

**Тузгытып яту** Шактый озак вакыт тузгыту. *Күптән йөрмәгәннәр, ахры – кайчандыр тузан тузгытып яткан юлны куе чирәм күмә башлаган.* Г.Гыйльманов

**ТУЗГЫШУ** *ф.* Үзара әрләшү, ызгышу, талашу

**Тузгыша башлау** Тузгышырга тотыну

**Тузгышып бетү** Тәмам тузгышу

**ТУЗДЫРГЫЧ** *с.* Кемнең дә булса тормышына, гаиләсенә зарар китерә торган. *Шул ук фатирда һәртөрле сөйдергеч имнәре, боздыргыч тасмалары, туздыргыч дәвалары табарга мөмкин.* Г.Тукай

**ТУЗДЫРУ** I *ф.* 1) Вак, җиңел, очучан нәрсәләрне төрле якка тарату, очырту. *Каты җир өстеннән ак тузан туздырып себергән җәяүле буран аның болай да ярсып чәбәләнгән уйларын тәмам аздыра, --- түземлеген соңгы чиккә җиткерә.* А.Вергазов. *Төньяктан исеп куйган зәһәр салкын җил шул хат кисәкләрен туздырып, каядыр очыртып алып китте.* Х.Ибраһим

2) Җилфердәтү, тибрәтү (чәчне, ялны һ.б.ш. тур.). *Җил икесенең дә чәчләрен туздыра иде.* Р.Вәлиев. *Күктимер, кара ат --- хәтәр итеп кешни, башын чайкый, ялларын туздыра.* Р.Камал

3) Билгеле бер тәртиптә яки үз урынында торган әйберләрне урыннарыннан алып, урнашу тәртибен бозып, төрле якка ыргыту, тарату; чәчү. *[Үгез] баш бирми, янәсе. Арбаны вата, көлтәләрне туздыра.* Р.Ишморат. *Өйгә кем кергәнен, бар әйберне туздырып ни эзләвен дә аңлады Зәнфирә.* Ф.Садриев

4) Бербөтен нәрсәне җимерү, сүтү, таркату. *Балачакта ук кош ояларын туздыра идең.* Ф.Садриев. *Әтисенең исереп кайтып бөтен җирне туздыра торган гадәте бар, шунда кулына эләгеп харап итә күрмәсен, дип курыкты малай.* А.Мансуров

5) *күч.* Куып тарату, тар-мар итү. *Хәтта Колчак гаскәрләрен Урал тауларыннан көнчыгышка куып, туздырып чыгарган чакта, бер көнне акларның контрһөҗүме вакытында могҗиза белән генә аларга әсир эләкми кала.* З.Зәйнуллин. *Чыңгыз чираттагы яуларының берсендә Тангут патшалыгын туздыра.* А.Хәсәнов

6) *күч.* Бик нык ачулану, шелтәләү. *– Ачуланган, – дип уйлады Хәлим, – мөгаен, туздыра инде бүген.* И.Гази. *Туздырып алып чыгып китә дә юл буена игәүли хатыны, кайткач йокы күрсәтми котыра.* К.Кара

7) *күч.* Кирәксезгә, юк-барга сарыф итү. *Кемнәрдер булган байлыгын Канар утрауларында туздыра, кемдер Урта диңгез ярында сарайлар сала ---.* Т.Миңнуллин. *Алисә уңга-сулга акча туздыра торган кыз түгел, һәр тиенен чутлап кына тотар.* Р.Габделхакова

**Туздыра бару** Рәттән, эзлекле рәвештә туздыру. *Тапкан малларын икәүләп туздыра баралар.* Р.Батулла. *--- Мин акчасыз кеше түгел. Ләкин мин аңа табынмыйм. Кергәнен туздыра барам.* Р.Фәйзуллин

**Туздыра башлау** Туздырырга тотыну. *Рәтләр арасыннан очып кына йөргән Дамский аңа каршы уйнаучыларны берәм-берәм туздыра башлады.* А.Хәсәнов. *Халык имансызлана төште. Төшмичә соң, көн саен, адым саен Аллаһы Тәгаләгә тел тигереп, мәчетләрне туздыра башлагач.* Н.Әхмәдиев

**Туздыра бирү** Бернәрсәгә карамастан туздыруын дәвам итү

**Туздыра килү** *к.* **туздырып килү**

**Туздыра тору** Озак вакыт туздыру; берәр эш-хәлгә кадәр туздыру. *Улы укуын тәмамлап, эшкә керә, акча таба тора, әнисе туздыра тора.* Безнең гәҗит

**Туздыра төшү** Бераз туздыру; тагын да ныграк туздыру. --- *Качалов театры каршындагы студиядә укып йөргән чандыр гәүдәле, --- беленер-беленмәс күкрәкләре өстенә бөдрә толымнарын туздыра төшеп салган икенче курс студенткасын Рәхилә роленә алып кайта.* Сәхнә

**Туздырып алу** Бераз гына туздыру. *Тәгәрмәчләр туздырып алган тузан борынга, авызга керә, арбага уралып, безне озата бара.* Г.Галиев. *Кинәт күңелендә тулган хисләрдән Ләмига Изаелның чәчләрен туздырып ала.* Р.Гаязетдин

**Туздырып ату** Кинәттән туздыру. *Мунчадан чыгып, чәчләремне туздырып аткан килеш, кечкә эңгер хозурлыгында йөзәргә --- дип, ялгызым гына утырган идем.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Килгән режиссёр – театр өчен чит режиссёр. Килер дә монда, үзе теләгәнчә булмаган нәрсәләрне күрер. Берәмберәм шуларны туздырып атар.* Ю.Сафиуллин

**Туздырып бетерү** Тәмам, тулысынча туздыру. *Әниең ул акчаларны күптән туздырып бетергәндер инде.* Г.Камал. *Без инде үзебез тудырасы буыннар өчен дигән энергияне туздырып бетереп барабыз икән.* С.Ибраһимова

**Туздырып җибәрү** Кинәттән туздыру. --- *Каршыдагы таллар арасыннан нәрсәдер очып чыкты да учакның сүнеп бетмәгән күмерләрен туздырып җибәрде.* Җ.Юныс. *Һаҗәр бөдрә чәчләрен туздырып җибәрде ---.* Г.Хөсәенова

**Туздырып карау** Туздырырга омтылу. *Кеше башына икешәр йомран тия, боларын сатып, акчасын туздырып карыйк әле ---.* К.Кәримов

**Туздырып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими туздыру

**Туздырып кую** Туздырган хәлгә китерү

**Туздырып ташлау** *к.* **туздырып ату**. *Шулчак бөтен кәгазьләрен үтәли җил туздырып ташлый.* Ф.Баттал. *Олылар чиркәүне туздырып ташлагач, авылның малай-шалае әлеге контораны туздыра башлады.* Г.Рәхим

**Туздырып тору** Һәрвакыт, гел туздыру; хәзер туздыру. *Кар берәмтекләп, сирәкләп яумый, ә кушучлап йөзгә сибелгән су кебек: көчле җил, ачу белән, аны каядыр бертуктаусыз түгеп, туздырып тора.* Р.Кәрами

**ТУЗДЫРУ** II *ф.* 1) Еш һәм озак кулланып таушалдыру, искертү, гамәлдән чыгару. *Аягындагы күн итекләренә генә күз сал син, гомер туздыра алмассың.* М.Хәсәнов. *Вакыт җан иясен картайта, әйберләрне туздыра, берәүне дә аямый.* Н.Әхмәдиев. *Ышанмасаң, әнә егетләрдән сора, мин – дүрт-биш аккордеон туздырган кеше.* Р.Миңнуллин

2) *күч.* Картайту, хәлсезләндерү; таушалдыру. *Гомумән, йөрәкне нык туздырган ике һөнәр бар: ихлас укытучы, чын режиссёр.* Р.Батулла

**Туздыра бару** Эзлекле рәвештә, рәттән туздыру. *Киемнәре яхшыдан булса да, бүреге генә иске. Әшкә кия торганы. Бүтәне юк шул. Малайлары киеп туздыра бара.* Ф.Яхин

**Туздыра төшү** Тагы да ныграк туздыру; аз гына туздыру

**Туздырып бетерү** Бик нык туздыру

**ТУЗМА** *с.* Тузгып, күпереп торган. *Егермеләп кеше --- сәхнәдәге тузма чәчле, ачык изүле ораторның сөйләгәнен тыңлыйлар.* И.Гази. *Тузма башлы төз наратларның шәүләләре тын суда чагыла.* Г.Гобәй

**ТУЗУ** I *ф.* 1) Вак, җиңел, очучан әйберләр төрле якка очып таралу. *Бальягарда тузан гына тузып калды.* К.Кәримов. *Тагын туздЫ буран, туздЫ кар, Табигатьнең төрле көне бар.* А.Нәҗми

2) Тәртипсез рәвештә төрле якка таралу, сибелү. *Каен яфраклары туздЫ Минем чәчләрем кебек.* Ә.Ерикәй. *Ә башында бернәрсәсе юк: чәчләре тузып, күзләренә төшеп тора.* В.Нуруллин

3) Әйберләрнең билгеле бер урнашу тәртибе бозылу, чуалу; тәртип бетү. *Тузып яткан шалаш эче, самогон шешәсе --- барысыннан да ачыграк булып күз алдында гәүдәләнделәр.* Г.Гобәй. *Өй эче тузган.* Р.Батулла. *«Оям туздЫ!» дигән уй йөрәгене өтеп алды...* Р.Хәбибуллина

4) Оешкан бер төркем таралу, таркалу. *Зур таш бинаның эче үзалдына бер завод, фабрика яки тузган умарта оясы шикелле гөрләп тора.* Г.Ибраһимов. *Олылар күрсә ачуланалар, кош оясын туздырырга ярамый, үз ояң тузар, диләр. Алар сүзе дөрескә чыкты: Кучтавылдагы оя да туздЫ, Янтыктагы оя да туздЫ.* Н.Фәттах

5) *күч.* Җимерелү, бетү, таралу, юкка чыгу

6) *күч.* Бик каты ачулану, әрләү, дулау. *Тик артыгын дулап, тузып булмый, Күпме ярсысаң да узып булмый Егерме биш яшьлек акылны.* Р.Миңнуллин. *Дуамал тамада тагы туза: – Кайда баш кодагый?* Р.Камал

7) *күч.* Үзара бәйләнешү, ярсу, усаллану, тәртип бозу. *Исмәгыйльнең эчеп, тузып йөрүе, төрле начарлыкларны эшләве турында сөйләгәч: – Председательлеккә сине үткәрәбез, – диешеләр.* Һ.Такташ. *Үзе кебекләр белән дөньяның маен сыкты: гүләйт итте, азды, туздЫ.* Н.Гыйматдинова

8) *күч.* Кирәксезгә, юк-барга сарыф ителү. *Бүген акча шактый туздЫ, шуңа күрә, уку беткәч, тулай торакка җиде сумлык трамвайда кайттым.* Г.Галимҗанова

9) *күч.* Бушка китү, юкка чыгу, акланмау, гамәлгә ашмау. *Өметләр тузу*

**Туза башлау** Тузарга тотыну

**Туза төшү** Тагы да бераз тузу

**Тузып алу** Тиз арада, аз гына тузу

**Тузып бетү** Тәмам, бөтенләй тузу

**Тузып китү** Кинәт кенә туза башлау. *Галиәкбәр агай тузып киткән вакытларда, абыстай хәзрәтне малай аркылы чакырт[а].* Ш.Мөхәммәдев. *Хәзер нишлисең инде, бармыйм дип кәҗәләнә башласаң, абзыкай я тузып китәр, аның талканы һәрвакытта коры була.* Ә.Еники

**ТУЗУ** II *ф.* 1) Озак куллану яки еш файдалану нәтиҗәсендә әйберләрнең ныклыгы югалу, искереп эштән чыгу; таушалып яраксыз хәлгә килү. *Броня туза, җимерелә, ә кеше чыдый, яши.* Х.Камалов. *Яратып кигән кием тиз туза шул ул.* К.Кәримов. *Авыл хуҗалыгы техникасы да, кыр эшләренә караганда, урман арасында күбрәк ватылып туза икән.* Г.Нурулла

2) *күч.* Картаю, зәгыйфьләнү, хәлсезләнү, өшәнү, бирешү. *Кырык биштән узган хатын нык туза.* Х.Камалов. *Бераздан, эшсез йөргән улына эче пошып, әнисе: – Ичмаса, бәрәңге сабагын чабар идең. Әтиең бик туздЫ, бик картайды бит, – диде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Бозылу, файдаланырлык, йөрерлек булмау. *Эшче кызы диләр аны. Юеш подвалларда төтен эчеп үскән ул. Каткан икмәк белән тәнен аның Тырнап йөрде Тузып беткән иске юл.* Г.Кутуй. *Сугышка хәтле Җиләкле халкы үз көче белән үзәк урамга таш җәйгән булган. Хәзер ул әкренләп туза башлаган, күп җирендә чокырлар хасил булган иде.* М.Вәлиев

**Туза бару** Торган саен ныграк тузу. *Искереп туза барган йортлар, җимерелә башлаган каралты-кура кемнең генә күңелен күтәрсен?..* Г.Галиева. *Без картая, туза барабыз...* Л.Шагыйрьҗан

**Туза башлау** Тузу билгеләре күренү. *Сугыш башланганнан бирле май заты күрмәгән паркеттан чыгамы ул тавыш, әллә бу киң балаклы купшы ирнең туза башлаган, ләкин пөхтә саргылт ботинкаларыннанмы*? М.Мәһдиев. *Кием-салымны, туза башлау белән, үзе ремонтлап куя.* Ф.Садриев

**Туза тору** Барысы да бер-бер артлы тузу. *Тора-бара ул рәсемнәр альбомнарга күчте, бала-чага уйнап, ерткалап, туза торды.* Ш.Галиев. *Узганнар уза торсыннар, Тузганнар туза торсын, Ниятем – саф, иманым – шарт, Каршыны Аллаһ орсын.* Ә.Гаффар

**Туза төшү** Тагы да ныграк тузу; аз гына тузу. *Бары түр яктагы өстәл өстендә генә пөхтә итеп дүрткә бөк-*

*ләнгән, чит-читләре саргайган һәм бераз туза төшкән ап-ак кәгазь бите ята иде.* Л.Шәех. *Гыймазетдиннән калган өй туза төшкән иде.* Сөембикә

**Тузып бару** Туза башлау, акрынлап тузу. *Көрән кофтасы тузып та бара инде.* Н.Хәсәнов. *Хәсбиҗамалларның каралты-кура тузып бара, өйдә ир заты юк иде.* М.Мәһдиев

**Тузып бетү** Тәмам тузу; барысы да тузу. *Сездән алган посылка бүзеннән ясаган кулъяулыклар югалып, тузып беткәннәр иде инде.* Х.Туфан. *Нәфисә әби чит-читләре тузып беткән альбомны кулына алды.* М.Галиев

**Тузып җитү** *к.* **тузып бетү**. *Имеш, ул машина, өр-яңа булмаса да, яртылаш та тузып җитмәгән булган?* Х.Камалов. *Табиб чакырганнар. Дарулар кулланганнар. Күрәсең, организм тәмам тузып җиткән булган, ул күзен йомган.* Татар театры

**Тузып килү** Туза башлау. *Әнә диван-караватның пружиннары кабыргага төртә, әнә, суыткыч тузып килә. Сәгыйтемнең чалбары тузып килә икән, хезмәт хакымны алу белән чалбар юнәтергә булыр, Алла боерса.* Ф.Яруллин. *Йорт-җирләре дә тузып килә.* Г.Галимуллина

**Тузып утыру** Әле, хәзерге вакытта тузу. *Әмма йортны бетерәсе килми әле. Тәрәзәләренә такта сугылган, тузып утыра, ләкин бетерәсе килми.* М.Мәһдиев

**Тузып яту** *сөйл.* Озак вакытлардан бирле тузу. *Автопаркта чәчелеп, тузып яткан иске бульдозерын көч-хәл белән сафка бастыра алгач, ул, ниһаять, кырга көзге сукага чыкты.* Х.Ибраһим

**ТУЗЫЛУ** *ф.* 1) *к.* **тузу** I (*1–2 мәгъ.*) **тузгу** I (*1–2 мәгъ.*); таралу, сибелү. *Дөньясы тузылган, эшләрендә тәртип беткән.* Г.Ибраһимов. *Салкын боз астында чәчләре тузылып яткан үле гәүдәсен күз алдына китерү белән, чәчләре үрә торды.* Һ.Такташ. *Һава тын, завод торбаларыннан кара төтеннәр, әкрен генә тузылып, кыекланып китә иделәр.* Ш.Камал

**Тузыла башлау** Тузылырга тотыну. *Шуннан соң безнең халык тарала-тузыла башлый да инде.* Җ.Юныс

**Тузыла төшү** Бераз тузылу. *Нәкъ шул диван турында, стенада, зур ак сакаллы, тузыла төшкән озын ак чәчле, зур чал мыеклы --- Маркс басып --- тора.* Г.Ибраһимов

**Тузылып бетү** Тәмам, бөтенләй тузылу

**Тузылып китү** Кисәк кенә тузыла башлау

**Тузылып яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта тузылган булу. *Гөлкәй, Рәмиләнең тузылып яткан берничә китабын кулына алып, уку залыннан чыкты.* Х.Ширмән

**ТУЗЫМТЫК** *и.* Тузган булу, тузу дәрәҗәсе, тузганлык

◊ **Тузымтыгы яматай** Әйберләрнең тузып, кешенең картаеп, ямьсезләнеп калуы. *Бу чүпрәкнең тузымтыгы яматай.* **Тузымтыкка әйләнү** Тузып, искереп, таушалып бетү. *Күлмәгем тузымтыкка әйләнгән*

**ТУЗЫНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тузыну**. *Артык тузындырма әле бу кызыңны*

**ТУЗЫНКЫ** *с. к.* **тузгын**. *Карт өянке һәм кыргый усак агачларының тузынкы чәчләре арасында, кара чебен төсле, кара каргалар кайнаша.* Ш.Камал

**ТУЗЫНУ** *ф.* 1) Арлы-бирле йөгерешү; ду килү. *Чикмән белән капланган берәү йөгереп кереп бии башлый. Биеп йөргән кыз кача. Бүтәннәр тузынмыйлар.* М.Фәйзи. *Ак айгыры, тыныч кына солы күшисе урынга, ишекле-түрле тузынып йөри иде.* Ф.Яхин // Ыгы-зыгы килү, шаулашу. *Бүген алар, сабырсызлык белән җыенып, тузынып, ашлар әзерләп, кунаклар көтә иделәр.* Ш.Камал

2) Бик нык ярсу (стихия, табигать күренешләре тур.). *Җил ачынып, тузынып кар ургыта. Атлар җилгә яннарын куеп тора.* Р.Батулла. *Яз быел бик йөгәнсезләнеп, дулап, тузынып килде.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Бик каты ачулану, дулау, тавыш-гауга чыгару. *Тузыныпмы-тузына минем әти-картлач.* Н.Фәттах. *Шунда да иплән кенә җайларга-көйләргә тырышып карады мине: – Алай ук тузынма әле, Өлфәт!* В.Нуруллин

**Тузына башлау** Тузынырга тотыну. *Мондыйларны күреп, Илсөяр холыксызлана, тузына башлый, ә кайчакта бөтенләй икенче кешегә әверелеп, үзенә ялгыш кына кагылып киткән егетләрне дә ачуланырга тотына иде.* Ф.Яруллин. *Тагын да үсә-үсә шунысы да беленә: кыз тиктомалдан котырына, тузына башлый.* Н.Гыйматдинова

**Тузына төшү** Тагы да ныграк тузыну

**Тузынып алу** Аз гына тузыну. *Бу көтелмәгән хәбәрдән халык башта айнып киткән кебек булды, һәркем башта өендә, аннан урамга чыгып тузынып алды, дулап маташты.* Ф.Бәйрәмова. *«Я вам покажу, собачьи дети!» – дип, янә бер тузынып алгач, утраудан чыгу юлына кузгалды.* И.Сираҗи

**Тузынып йөрү** Озак вакыт дәвамында тузыну. *Ә теге алда сөйләгән вакыйга апамның, әни фамилиясенә күчәм, дип тузынып йөрүе белән тәмамланды.* Э.Шәрифуллина

**Тузынып китү** Кинәт тузына башлау. *Ул кемнең кем булуына, кайда нишләвенә карап тормый, юкка гына ачуы чыга да тузынып китә, аты-юлы белән акыра башлый.* Х.Камалов. *«Без дә үз кеше!» – дип тузынып китте хан.* М.Әмирханов

**ТУЗЫШУ** *ф.* Талашу, ызгышу, даулашу. *Берлек итик, Харам безгә борынгыча тузышырга.* Г.Камал. *Алар күп вакыт шулай тузышалар иде, ә эш барыбер рәтләнми иде.* Г.Толымбай

**Тузыша башлау** Тузышырга тотыну

**Тузыша тору** Бертуктаусыз тузышу; билгеле вакыт дәвамында тузышу. *Кызышып тузыша торгач, хатын баланы алып кайтып китә.* Идел

**Тузышып алу** Аз гына тузышу

**Тузышып китү** Кинәт тузыша башлау

**ТУЙ** *и.* 1) Өйләнешү уңаеннан оештырылган чакырулы мәҗлес һәм гомумән өйләнешү йоласы. *Рәсимә тагын авыр сулады да әйтте: – Ярар инде, биш туй ясап бирдем, тагын төпчек кызыбызга да ясап бирсәм, дөнья түгәрәкләнә, – диде.* М.Мәһдиев. *Туй мәҗлесенә кияү ягыннан апалары-җизнәләре һәм авылдагы туган-тумачадан тыш, хезмәттәшләре дә килгән иде.* Д.Гайнетдинова

2) *сөйл.* Шул мәҗлестә катнашучылар, туй кунаклары; туйчылар. *Бу*

*тавыш ерак һәм әкрен булса да, капка төбендә торучы бер егет яман кычкырып җибәрде: – Туй килә-ә! Әйе, туй килә, туй!* Ә.Еники

3) Нинди дә булса шатлыклы, тантаналы вакыйга уңаеннан үткәрелә торган бәйрәм яки мәҗлес. *Бәби туенда Миңнулла алты тапкыр үзе башлап җырлады ---.* М.Мәһдиев. *Җәй көне урманда авыл халкы --- күңелле Сабан туйлары уздыра, печән чаба.* Р.Кәрами

4) *сөйл.* Эт, мәче кебек хайваннарның кушылу өчен бергәләшеп, күпләп йөрүе; өегү. *Март башларындамы, апрель ахырындамы, бик буранлы ямьсез бер көндә безнең Курмышта булды ул эт туе.* А.Хәсәнов. *Сулыш алганда тамак төбе, күкрәгенең өске өлеше, мәче туен хәтерләтеп, төрле тавышлар чыгарып сызгыра.* Г.Галиев

5) Җыен, өер, төркем. *Төрмә күңелсез, анда тычканнар һәм сәке тулы кандала туе.* М.Җәлил. *Тирә-якта чикерткә туе.* М.Хәсәнов. *Бүре туе һәр кич өстәл кора.* С.Якупова

◊ **Туеңа кадәр төзәлер** Берәр җирен бәргән, яралаган кешене юату сүзе. *Әхәт, аяк бармагын тотып, еларгамы, еламаскамы дигәндәй тора. [Исхак:] Туеңа кадәр төзәлер, елама.* Һ.Такташ. *Мин исә аның ярасына әрекмән яфрагы яптым да, зурларча итеп: «Туеңа кадәр төзәлер!» – дидем.* Ирек мәйданы. **Туйга очу** Ана корт, ата корт белән очрашу өчен, умартадан очып чыгу. **Туйдан качкан кыз** Мөһим мәсьәләне ашыгыч хәл иткәндә, кирәкле кешенең булмавы турында. *Озын сүзнең кыскасы, без бүген монда иң элек Сәүбан Бикчәнтәевнең отчётын тыңламакчы идек, ә ул менә, туйдан качкан кыз булып, күренми дә күренми.* Ф.Хөсни. **Туйдан соң думбра кагу** Берәр эш хәл ителгәч, эшләнгәч кенә шул эшне икенче берәү күтәреп чыгу турында. *[Сәрвәр] кәгазь-каләм алып җавап язарга утырды. Дөресен әйткәндә, монда инде узган эш иқәнлеген ул яхшы белә. --- Димәк, аңарга хат язып маташу туйдан соң думбра кагу гына булып чыгачак.* Ф.Хөсни. **Туйдан соң (туй узгач) дөмбер (дөмбергә)** Мәсьәлә хәл ителгәч, соңарып башланган эшнең файдасы, кирәге булмау турында. *Туйдан соң дөмбер, дигәндәй, беткәннән соң уйлавыңда ни файда!* К.Тинчурин. *Җамали, синең бу чыгышың «туй узгачтан дөмбергә» дигән кебегрәк булды. Тавышка куйганчы сөйләргә иде.* Т.Гыйззәт. **Туйдан соң (туй узгач) тукмак (тукмакка)** *к.* **туйдан соң (туй узгач) дөмбер (дөмбергә)**. *«Башкайларың кая иде синең,ниләр уйладың?» – дип кабатлый-кабатлый әй әрләде Миләүшә, әй әрләде. Тик ни файда, туйдан соң думбра, дигәндәй.* А.Әхмәтгалиева. **Туй узган** *к.* **туй узган, тун тузган** (*1 мәгъ.*). *Башлык Иблис: «Юк, хәзер соңдыр, – диде. – Туйлар узган ---», – диде.* Ш.Бабич. **Туй узган, тун тузган** 1) Кирәкле моменты, мизгеле үткән (эш тур.); 2) Картайган яки кеше арасында берәр ягы белән дәрәҗәсе төшкән (кеше тур.). *– Әйдәгез инде, безнең туй узган, тун тузган, – диде җеп катып утырган Бәдриҗамал.* Н.Кәримова. **Туй уйнау** Туй үткәрү, туй ясау; туй итү. *Бүген кушасың икән, киләсе кич атна көн дөбер-шатыр туй уйныйбыз.* Ш.Камал. *– Әллә туй уйнарга әзерләнәсеңме, Ихтыяр? – дип кызыксынып сораштылар.* Р.Вәлиев

**ТУ́Й АШЫ** *и. этн.* Туй мәҗлесендә куела торган махсус ризык, сый. *Туй мәҗлесендә туй ашы ун-унбиш төрле аш була. Әүвәле бал-май китерәләр, аннан соң гадәти ашларны берсе артыннан берсен китерә башлыйлар: пылау, гөбәдия, бәлеш, бөккән...* К.Насыйри

**ТУЙБАШЧЫ** *и. этн. к.* **туй башы**. *Сабирҗан ага туйдан туйга туйбашчы булып, казак акыннары белән җыр-өләң әйтүдә ярышып йөргән.* Н.Исәнбәт

**ТУ́Й БАШЫ** *и.* Туй мәҗлесен алып баручы; җырга, сүзгә оста хөрмәтле кеше; табынчы

**ТУ́Й БҮЛӘГЕ** *и.* Туй мәҗлесе алдыннан яки барышында егет яки кыз ягыннан бирелә торган бүләкләр. *Сезгә туй бүләге булсын бу яшел гармун!* Ш.Җиһангирова. *--- рәсемнең берсен – уң яктагы караватт өстендә эленеп торганын – тулай торакта бергә яшәгән кызлар туй бүләге итеп китергәннәр иде.* М.Маликова

**ТУ́ЙГАНЧЫ** *рәв.* 1) Тук булганчы, туеп җиткәнче. *Туйганчы ашамасак та, безнең хет, елаганда, баштан сыйпарга әниебез, тыңламаганда каешлап алырга әтиебез бар.* Ф.Яруллин

2) Теләгән кадәр, ихтыяҗны канәгатьләндерерлек; җитәрлек, мул итеп. *Хәкимҗан --- дәү кулларын шап-шоп бәреп туйганчы кул чапкач, тып-тын утырган Былбылнисасына карады да туктап калды.* М.Мәһдиев. *Шулай бит ул: әле көннәр күп кебек, очрашырсың да, туйганчы сөйләшерсең дә шикелле, ә карасаң, вакыт үтеп тә киткән, хушлашыр сәгатьләр килеп җиткән.* М.Маликова

**ТУЙГЫЗУ** *ф. к.* **туйдыру**. *Учагыннан ут өзмәс, Улын-кызын туйгызмас.* Мәкаль

**ТУЙГЫЛЫКЛЫ** *с. диал.* 1) *к.* **туклыклы**. *Солы – атка туйгылыклы азык*

2) Туйганчы ашарлык

**ТУЙГЫЛЫКСЫЗ** *с. диал.* 1) *к.* **туклыксыз**. *Туйгылыксыз ботка*

2) Ашап туймаслык. *Ашап туйгылыксыз тәмле булган ит бәлешегез!*

**ТУЙГЫСЫЗ** *с.* Үзеннән алда килгән хәл фигыль белдергән эш-хәлне дәвам итәргә теләүне яки кемгә яисә нәрсәгә дә булса соклануны аңлата; туймаслык. *Карап туйгысыз, һушларны алырдай сылу иде аның Гөлүсәсе бу минутта.* М.Хәсәнов. *Арыш башын уып, табада кыздырсаң, ашап туйгысыз бер ризык була.* М.Мәһдиев

**ТУЙДЫРУ** *ф.* 1) Тук хәлгә китерү, тук итү, тукландыру. *Хәмидә, баласын имезеп туйдыргач, искесен җәйде.* М.Гафури. *Үз тамагын үзе туйдыра алган кеше аларда өлкәннәрдән санала, ә тамагын туйдыра алмаган кеше исә я бик яшь, я бик карт, я бик тә ялкау була.* М.Юныс

2) Ашату, тукландыру; азык, ризык бирү. *Лапас буенда үги әнисе тавыкчебеш туйдыра иде.* Н.Хәсәнов

3) Берәр ихтыяҗны канәгатьләндерү. *Йокыгызны туйдырып, өйдәге эшегезне бетергәннән соң гына, фермага килә идегез ---.* Т.Гыйззәт. *Озын, яшел вагоннардагы кешеләр төрлесе төрле эштә: кайсы кичке чәйне эчә, кайсы калган йокысын туйдыра ---.* А.Алиш

4) Тәэмин итү; табыш чыганагы булып тору. *Авыл хуҗалыгын белмәгән башы белән Ихласка нинди провокацион сораулар биреп маташкан бит! Имеш, колхоз-совхозлар үз-үзләрен дә туйдыра алмаганда ни дип аларны асрап ятасыз да нишләп таратмыйсыз?* А.Гыйләҗев. *Әйдә ярар, секретарьларга гел халкына зарар салып кына утырасы түгел, яхшылык та эшләсеннәр. Халык туйдыра бит аларны, татар җирендә үскән ризык ашыйлар бит алар.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Үз тәрбиясендә тоту, асрау. *Картайган анасы --- кешеләргә җеп эрли, ямау ямый, кер юа, шулай итеп улын туйдыра икән.* А.Алиш. *Атны мин сиңа бирәлмим. --- Миңа, карт кешегә, семья туйдырырга кирәк.* Ф.Бурнаш

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса еш кулланылып яки берәр эшнең озакка сузылып йөдәтүе, ялыктыруы. *Кала шаушуы бик тиз туйдыра аны.* М.Хәсәнов. *Кыш буе тук, иркен тормыш, театр, бильярд, рестораннар туйдыра бит.* М.Мәһдиев

**Туйдыра башлау** Туйдырырга тотыну. *Ләкин гелән-гелән ак күмәч белән майлы ботка да туйдыра, дигәндәй, тора-бара Николай Максимовичның такылдаулары безне туйдыра башлады.* Г.Әпсәләмов. *Сүз көрәштерү аны тәмам туйдыра башлады.* Х.Камалов

**Туйдыра төшү** Бераз туйдыру

**Туйдырып алу** Тиз генә туйдыру. *Тамак туйдырып алганнан соң, ике баҗа ишегалдын рәткә салырга кереште.* Ф.Яруллин. *Тамагын туйдырып алгач, бала йоклап китте.* Г.Гыйльманов

**Туйдырып бетерү** Тәмам туйдыру. *Иске ыштан кебек туйдырып бетергән артистларга акча әрәм итәргә башыма тай типмәгән әле.* Ф.Яруллин. *Бригадирга халык әле теге, әле бу ихтыяҗы белән килә, кайберәүләр, туктаусыз теләнеп, туйдырып бетерә.* Ф.Садриев

**Туйдырып җибәрү** Тиз арада яки кинәттән туйдыру. *Гел үзең генә укыту, өйрәтү дә туйдырып җибәрә.* М.Мәһдиев. *Әтиең чакырганда, мин, артык тиз арада туйдырып җибәрүемнән куркып, үземнең очрашасым килсә дә, юк сәбәпне бар итеп, кайчак баш тарткалый торган идем.* К.Тимбикова

**Туйдырып карау** Туйдырырга тырышу. *– Я, я, – дигән Аю, – бүләгеңнең нәрсәгә яраклы икәнен күрсәт. Җанымның да тамагын туйдырып карыйк.* Ф.Яруллин. *Рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып, урыс балаларын үз телләренә дә өйрәтеп тамак туйдырып карадым.* Н.Сафина

**Туйдырып килү** Элек-электән, даими туйдыру. --- *Энем Мөхәммәтхан, бу көнгә кадәр без сине җәмәгатьләрең белән туйдырып килдек, анысы өчен рәхмәт әйтсәң дә, әйтмәсәң дә – үз эшең.* К.Тинчурин. *Гомер-гомергә шушы басу туйдырып килде, читләргә ялынмадык.* Р.Вәлиев

**Туйдырып кую** Алдан туйдыру; кинәт туйдыру. *Аннары тәрбиячеләр дә анасы килгәнне көтеп тормыйлар, еламасын өчен, сабыйның тамагын туйдырып куялар иде.* М.Маликова. *Марсельнең кыланчыклыгы кайчакта туйдырып та куя.* Р.Миңнуллин

**Туйдырып тору** Һәрвакыт, гел туйдыру; әле, сөйләү моментында туйдыру. *Нинди инсафсыз, унсигез ел бөтен җәмәгатен безнең өстән туйдырып торуы җитмәгән, байның бөтен малын кочакламакчы була!* Г.Исхакый. *Кара елан --- өч көн буена яшь бөркетләрне шулай туйдырып торган ул.* Ф.Яруллин

**ТУЙДЫРУЧЫ** *и.* Караучы, тәэмин итүче, асраучы, үз тәрбиясендә тотучы. *Такта траптан менеп килгән Нәзифәне күрү белән, аның шатлыгы йөзенә чыкты: «Әһә, менә туйдыручыбыз да килеп җитте».* С.Сабиров. *Сараттәй Рафиканың битеннән, маңгаеннан үбә-үбә: «Җылытучым, туйдыручым, Ходай биргәнем минем», – дип такмаклый-такмаклый елады.* Г.Галиев

**ТУ́Й ИТҮ** *ф.* 1) Туй (*1 мәгъ.*) үткәрү, туй уздыру. *Тугыз суем суеп, тугыз көн туй итеп, баеп, әле дә булса торалар, ди.* Әкият. *Алар борынгыча яшәгәннәр, борынгыча туй иткәннәр: кәләш үзенең кияүен зөфаф кичендә беренче тапкыр күргән.* М.Маликова

2) Бәйрәм итү, бәйрәм тантанасы ясау. --- *Якты өй эчендә берьюлы меңләгән авызлар чапылдады, итләр чәйнәлде, алтын, көмеш табакларга тиеп, сөякләр, пычаклар, кашыклар шакылдады. Җиңүчеләр туй иттеләр.* Н.Фәттах

**ТУ́Й КАУРЫЙЛАРЫ** *и. биол.* Аталану вакытында кошларда чыга торган махсус каурыйлар

**ТУ́Й КЫЛУ** *ф.* **туй итү**. *Кыз гомереңнең унсигезенче язына аяк басканда, һәр ике йорт, зур туй кылып, аны каенаталар йортына озату чараларын күрү уена төштеләр.* Г.Ибраһимов

**ТУЙЛА́У** *ф.* Туй үткәрү, туй ясау. *Туйлап килен төшерү булмаса да, Наҗия артыннан әллә никадәр урынҗир нәрсәсе, өй җиһазы ияреп килде.* Ә.Еники. *Ә сез менә, туйлап өйләнешмәсәгез дә, инде алтынчы елыгызны әйбәт кенә яшәп ятасыз!* В.Нуруллин

**Туйлап алу** Тиз генә, тиз арада туйлау. *Тагылый да тагылый сулар, һай, Ермак булып агып калдылар. Баткан җирләреннән чыкты ла ай, Аккошкайлар туйлап алдылар.* Җыр

**Туйлап кую** *к.* **туйлап алу**. *– Я килеңнең дә син пешмәгәннән җаны бизәр! – дип, атна ярым үтмәс борын туйлап та куйдылар.* Ф.Яхин. *Моңа карап кына өйләнмәдем инде, Ходай шулай язган, шалт итеп кенә туйлап куйдык.* Татар заманы

**ТУЙЛАШУ** *ф. к.* **туйлау**. *Мин быел туйлашкан идем, биш баш сарык китте!* Г.Бәширов. --- *Ул күздән югалуга, рәхәтләнеп бәйрәм итәргә, туйлашырга тотыналар.* Ф.Яхин

**Туйлашып алу** Тиз генә, тиз арада туйлашу

**Туйлашып кую** Тиз арада яки нәрсәдер җиткәнче туйлашу

**ТУЙЛЫК** *с.* **1.** Туйга дип билгеләнгән, туйга җитәрлек. *Туйлык сума ясар өчен, ике ел буена ике сменада эшләдем.* К.Тинчурин. *Хәмдия түти, --- мәрхүм ире матур өметләр баглап салган болындай йортын мунчадай өйгә алыштырып, сыерын кәҗәгә әйләндереп, туйлык акча хәстәрләде.* Ф.Баттал

**2.** *и. мәгъ.* Туй өчен билгеләнгән акча, мал. *Аерым хуҗалыклардан акмаса да тамып тора бит сиңа. Шулай акрын-акрын тама торгач, туйлык та*

*булып куя ул. Мин үзем шулай өйләнгән кеше.* К.Нәҗми. *Юк шул, чибәркәем, туйлык җыеп булмый, пенсия акчасы бетеп бара.* Ф.Дәүләтбаев

**ТУЙМАС** *с.* 1) Күп ашаучан, ашапашап та җитми торган; ачкүз. *Нинди туймас каракош ул, нигә көннәр буена шул тирәктә утыра, нигә аны, ниһаять, укчылар укка алмыйлар.* М.Хәбибуллин. *Мин, үземә карарга тапшырылган каз бәпкәләрен комсыз тилгәннәр һәм туймас тамак каргалар иркенә калдырып, көннәр буе машиналар янында чуала башладым.* Ф.Яруллин

2) Комсыз, барына канәгатьләнми торган. *Хак: карышкан саен Наилә Сабитка ныграк ошады, туймас каны котырды, нәфесе, җиде башлы дию булып, аның назлы тәнен теләде.* А.Гыйләҗев. *Әнә хатын-кыз затыннан булган башка җан ияләре бер дә туймас нәфесле түгел югыйсә...* Ф.Баттал

**ТУЙ-МУЙ** *җый. и. к.* **туй** (*1 мәгъ.*). *Балабыз [солдаттан] калса, туй-муй ясап ташларбыз.* М.Гафури

**ТУЙРА** *и.* 1) Яшь имән. *Тау тарлыгы каршындагы буар елан --- таш-тау арасыннан шуышып чыккан да болын уртасындагы яшь туйрага уралган.* Н.Фәттах. *Анда ялгыз кабер тора, кабер өстенә бер-ике үлән шытып чыккан, аяк очында ять-яшь имән – туйра үсеп утыра.* Р.Батулла

2) Агач төбеннән чыккан яшь үренте, бәбәк, яшь ботак. *Безнең инешнең төбендә Туйра таллар бар икән.* Җыр. *Гүя Өязе буйларының меңләгән карт өянкесенең, меңләгән яшь тал туйрасының семәрләнгән көмеше, кыллы кыңгырауларда зеңгелдәп, коелып төште ---.* А.Хәлим

3) Куаклык. *Иж суын беләсең. --- Бер ягында – туйра, таллыклар, икенче ягында – биек-биек сөзмә таулар.* Т.Гыйззәт. *Сунарчы туйралар белән капланган сыртка күтәрелде, күтәрелгән саен, агачлар эреләнә барды, эреләнә барды.* Ә.Әминев

4) Юкә кайрысы. *Туйрасы купкан нәзек-нечкә читән агачлары, читтән караганда, рәт-рәт булып тезелешеп, үләксә кабыргаларын хәтерләтәләр иде.* М.Хәсәнов. *Минем туган авылым Борбаш урманга бик якын урнашканлыктан, бала чакта табигатьнең бу чиксез мөлкәтен «имеп» яшәдек: халык чабата өчен юкә каезлап, шуның туйрасын ташыды ---.* Татарстан яшьләре

5) Агач төбе. *Туйра яру*

**ТУЙРАЛЫК** *и.* 1) Куаклык

2) *диал.* Имәнлек; яшь имәнлек. *Урман авызындагы туйралыктан әчкелтем ис аңкып торган саллы гына күсәкләр кисеп алдык.* А.Гыйләҗев. *Башлыча ботак-чатаклы, кәкре-бөкре имәннәр үсә торган бу туйралыклардан колхоз да, авыл советы да үз кирәгенә файдалангалый.* Г.Рәхим

**ТУ́Й РӘЕШЕ** *и. биол. к.* **туй каурыйлары**

**ТУЙ-ТӨШЕМ** *җый. и.* 1) Туй кунаклары, туйга килгән кунаклар

2) Туй мәҗлесе. *Анда һәркемдә туйтөшем, килен озату була.* З.Бәшири. *Кыңгыраулар тагып, туй-төшем ясап өйләнә...* Г.Исхакый. *Вакыты булмаганда вә туй-төшемнәр күбрәк булганда, атнасы белә кермичә дә каладыр иде.* Ф.Кәрими

**ТУЙЧЫ** *и.* Туй мәҗлесендә катнашучы кеше. *Ничек булса да булды: туйчыларның барчасы, башларын җиргә иеп, кире авылга кайтырга мәҗбүр булдылар.* М.Акъегет. *Балачага дөньяларын онытып туйчыларны күзәтәләр.* А.Нәҗми

**ТУК** I *с.* **1.** 1) Туйганчы ашаган; ач булмаган. *Үзем аерым йорт салып кервә алсам да, элекке фатирымда калдым, чөнки биредә җан тыныч, тамагым тук --- иде.* А.Тимергалин. *Тук корсакка йокы тәмле була.* Р.Габделхакова

2) Туйганчы ашаган кешегә яки хайванга хас. *Машиналар килә торды, алардан нәкъ бер буйдагы, бертөслерәк киенгән, сәламәт, тап-таза, тук кыяфәтле ирләр төшә торды.* А.Гыйләҗев. *Ара-тирә ил башлыкларының тук йөзләрен төшерергә дә туры килә иде.* Г.Гыйльманов

3) Тулы, тиешенчә матдәләрне туплаган; өлгереп җиткән, җитлеккән. *Тук башаклардан җылы, татлы ис аңкып, күңелне дәртләндерә.* М.Маликова. *Тук карабодай башакларының үзе төслерәк кызгылт көрән ул.* А.Хәсәнов. *Игендә тук орлык кына буламы?* А.Хәлим. *Тук чикләвек*

4) Игеннәр уңган, ризык, ашамлык запаслары мул булган (ел, сезон тур.). *Тук елларда бу уенга егетләр, хәтта олылар да катнаша иде.* М.Галәү. *Ә теге елга – игенле-печәнле тук елга килсәк, ул елның да көзе авыр булды.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Көр, тулы, таза (кеше тур.). *Тук кына, симез генә, түгәрәк кенә полковник безгә күзен акайт[ты].* Г.Тукай. *--- аяусыз ярсулык белән өргән тук этләрнең каешыннан тартып, үзара нидер сөйләшә-сөйләшә карап торуы немец солдатларына ләззәт бирә иде, күрәсең.* М.Галиев. *Тук атларны җилдертеп, авыл арты авылларны үттеләр.* И.Хуҗин

6) *күч. сөйл.* Иркен, таза, бай (тормыш тур.). *Барысы аны бай өйгә, тук һәм һәр яктан канәгать семья эченә кабул иттеләр.* Ә.Фәйзи. *Атасыз-анасыз, йортсыз, назсыз калган, яңарак кына бәхетле, тук, матур киемле, күп уенчыклы тормышта яшәгән балаларның кичә генә әти-әниләре – «зур хуҗалар» – яхшы эштә иде.* З.Зәйнуллин

**2.** *и. мәгъ.* Туйганчы ашаган кеше. *Тук кикерер, ач сикерер.* Мәкаль

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Туйганчы ашап, ачлык сизмичә. *Башка нәрсә чәчергә хәле җитмәгән ярлылар быел үзләренең унунбиш таяк тарылары белән дә, һич булмаса, берничә ай тук торуны уйлап, зур дәрт белән --- урырга, чабарга тотындылар.* Г.Ибраһимов

2) Иркен, мул тормышта. *Тук яшәргә теләгән кеше үз-үзенә генә ышанырга тиеш.* М.Галәү

**4.** *хәб. функ.* Нинди дә булса бер нәрсәгә мохтаҗ түгел; җитәрлек. *Халык фуражка-муражканы кия башламас борын кара акылга тук иде.* Ф.Әмирхан. *Начальник халкы ач түгел. Утырган саен, авыз тутырып ипи ашый, итмай ашый. Атлары да тук, балалары да тук.* Н.Фәттах

◊ **Тук булу** 1) Канәгатьләнү, риза булып тынычлану. *Юк булганчы, сине күреп калам, Әле синең белән тук булам.* Н.Исәнбәт; 2) Күрәсе дә килмәү, күңел кайту. **Тук корсак** Туклык, байлык; иркен тормыш. *Дөньяда икенче*

*бер төркем хыялчылар да бар. Алар – тук корсактан, акыл бушлыгыннан, эшсезлектән, эч пошудан азынып хыялланучылар.* Г.Нигъмәти

**ТУК** II *иярт.* Агачка сукканда чыккан саңгырау тавышны белдерә. *Ул көчле, моңлы тавыш белән сөйләп китте: «Кисә башлаган утынны Балта белән тук та тук».* З.Зәйнуллин. *Җепне тартуга, булавкага асылынган бәрәңге тук итеп тәрәзәгә китереп бәрә.* М.Галиев

**ТУКАЛ** I *и. диал.* Мүкләк, мөгезсез сыер. *Сыерыбыз тукал булып чыкты*

**ТУКАЛ** II *и.* Яшь хатын (казак, кыргыз, ногай һ.б.ларда)

**ТУКАН** I *и. зоол.* 1) Челәннең бер төре

2) Кыекбаш уенының башка атамасы

**ТУКАН** II *и. португ. зоол. лат.* Тукрансыманнар отрядыннан Көньяк Америкада яши торган, гәүдәсенә карата артык зур томшыклы кош. *Эре кош – гаять зур борынлы тукан – төсе белән (попугайлардан) калышмый.* Физик география. *Болар – чәчәк нектары белән тукланучы кечкенә колибрилар, тутый кошлар, туканнар һ.б.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ТУКАТУ** *ф. диал.* Сихерләү. *Бу – тукатудан килгән авыру, аны төзәтеп булмый!* З.Бәшири

**ТУКЛАНДЫРГЫЧ** *и.* **1.** *а.х.* Үсемлекләргә кертелә торган өстәмә ашлама. *Азотлы ашламалардан аммиак селитрасын һәм аммоний сульфатын туфракны --- тукландыргыч сыйфатында да файдаланалар.* Х.Байчурова

**2.** *с. мәгъ. к.* **туклыклы** (*2 мәгъ.*). *Кайбер көннәрдә май урынына биткә сөртә торган тукландыргыч крем кулланалар иде.* Ватаным Татарстан. *Җиләк утыртканда, алар утыртыласы чокырга туклландыргыч катнашма салу да комачауламас.* Шәһри Казан

**ТУКЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Кемгә дә булса азык бирү; ашату, туендыру. *Дүртенче кыш инде ул табигать иркендәге хайваннарны ризык белән тукландыра.* Н.Гыйматдинова. *Ә менә урманнарның халыкка тормыш алып бару өчен булышлыгы тагын да зур. Алардагы байлык халыкны туклндыра, җылыта --- һәм сихәтләндерә дә.* Х.Садри

2) *а.х.* Үсемлекләргә өстәмә ашлама кертү. *Уҗым матур буласы, Тик бар туклндырасы.* Ә.Юныс. *Белгечләр, үсемлекләрне туклндырганда, чәчкечләр ярдәмендә туклндыруны иң әйбәт ысул диләр.* Мәдәни җомга

3) Нормаль торышы һәм эшчәнлеге өчен организмны кирәкле матдәләр белән тәэмин итү. *Моңарчы ярадыны уколлар белән генә туклндырып тотканнар, хәзер әкренләп азык бирә башларга кирәк.* Х.Камалов. *Майлар чәчне туклндыра, структурасын яхшырта, ялтыратып җибәрә.* Шәһри Казан

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса үсешенә җирлек, даими нигез булу. *Казанга күчеп киткәнче, --- якташларының күңел энҗеләрен, әхлакый мәгъныләрен күңеленә сеңдерүне дәвам итә. Бу байлык бөтен иҗатын туклндырып, нур бөркеп, эчке ышаныч биреп тора.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Берәр ихтыяҗны канәгатьләндерү. *Без, алтмышынчы еллар башында шигърияткә килергә омтылган яшьләр, үзебезнең яңалыкка булган комсызлыгыбызны Әнвәр Давыдов әсәрләре белән байтак туклндырдык.* Фән һәм тел

**Туклндыра башлау** Туклндырырга тотыну. *Кечкенә «төймәчекләр»дә берниндә дә файдалы матдә юк, шуңа күрә табиблар кызны торбачык аша махсус концентратлар белән туклндыра башлаганнар.* Шәһри Казан. *Бу районнарда күпьеллык үлән чәчелгән кырларны һәм уҗым басуларын туклндыра башладылар.* Татарстан яшьләре

**Туклндыра төшү** Тагын да туклндыру

**Туклндырып бару** Берсе артыннан икенчесен туклндыру

**Туклндырып килү** Билгеле бер вакыт дәвамында даими туклндыру. *Шушы кырлар ничәмә-ничә гасырлар буе туклндырып килде безнең авылларны, халык үрчеде, мәчетләр, яңа йортлар салды, келәтләр төзелеп торды.* М.Миначев

**Туклндырып кую** Алдан туклндыру. *Күпьеллык үләннәрне һәм уҗымнарны туклндырып та куйганнар.* Безнең Чирмешән

**Туклндырып тору** Һәрвакыт, гел туклндыру. *«Авыр булса да түзик, бүленгәнне бүре ашар, аерылганны аю ашар», – дип зарлана-зарлана таралышкан кардәшләребез ничәмә-ничә гасыр аю-бүреләрне туклндырып торалар икән, ни хәл итмәк кирәк?* А.Гыйләҗев. *Бит тиресе чиста һәм нәфис булсын өчен, аны гел туклндырып торырга кирәк.* Мәдәни җомга

**ТУКЛАНУ** I *ф.* 1) Берәр төрле азык белән ризыклану, ризык кабул итү; ашау. *Ашханәдә Гомәр Кырымның Чатыр тау үзәнендәге дала үләннәре белән тукланып иркендә йөрүче бия сөтеннән ачытылган тәмле кымыз эчте.* Г.Рәхим. *Шулай итеп, аның --- кайда туры килсә, шунда --- тукланып яисә тулай торакта коры-сары белән тамак ялгауларына да чик куелды.* Р.Кәрами

2) Нормаль үсеш өчен кирәкле матдәләр алу. *Алар тамырларын тирәнгә җибәреп, уңдырышлы туфрактан тукланып, көч алып, гөрләп үскәннәр һәм ныгыганнар.* Ә.Хәйруллин. *Үсемлек үзенең тамыры, сабагы, яфраклары ярдәмендә туклана.* Ботаника

3) *күч.* Берәр нәрсә белән канәгатьләнү. *Мәгърифәкәй, синең төсең сокланырлык. Нинди генә күңелгә дә тукланырлык.* Ш.Бабич. *Бар йөргән аңа бирде. Дөньяда аңардан да якын бер зат булмады. Күңеле, вөҗүде шул кыз белән тукланып, канәгатьләнеп торды.* Х.Камалов

**Туклана башлау** Тукланырга тотыну. *Маймылда аучылык гадәтләренең барлыкка килүен һәм шул нигездә аның даими рәвештә ит азыклары белән туклана башлавын бары шулай гына аңлатып була.* Н.Фәттах. *Мин бик ябык идем, ә җиләк-җимешләр белән генә туклана башлагач, өч килога кадәр тазардым да әле.* Шәһри Казан

**Тукланып алу** Тиз-тиз генә туклану. *Тукланып алганнан соң, Асылхан иң әүвәл чикләвек куаклыгы төбенә яңгырдан-җилдән саклана торган башлыклы җиңел кожанын җәйде.* М.Хәсәнов. *Пакетны томшыклары белән тишеп бушаттылар, андагы ризыклар белән тукланып алгач, ояларына менеп утырдылар.* Безнең гәҗит

**Тукланып карау** Туклану нәтиҗәсен сынау. *Ә син иписез яшәп, шул театр-концертларың белән генә тукланып кара!* Җ.Дәрзаман. *Безнең егетләр дә анда кереп, тукланып караганнар: «Сыйфат ягыннан бик нык калыша, ризыклар татар милләтенеке булудан ерак тора», – диләр.* Шәһри Казан

**Тукланып килү** Билгеле бер вакыт дәвамында даими туклану. *Шәүкәт командасы моңарчы, дәүләт паёгына кучәргә ашыкмыйча, юлга үзләре алган ризыклар белән тукланып килде.* А.Хәсәнов

**Тукланып кую** Алдан туклану; тиз генә туклану. *Безнең Россия халкы --- эш урынында обед оештырылмаган булса, бер-ике йөз грамм колбаса белән кефир яки йогурт белән тукланып куя ---.* Татар, уян!

**Тукланып тору** Әле, хәзерге вакытта туклану; озак вакытлар бертуктаусыз, еш туклану. *Татарлар арасында фарсы теленең киң таралуы, әдәбиятыбызның Шәрык классикасы белән дәвамлы тукланып торуы фарсы теленең мәктәп-мәдрәсәләрдә ныклап өйрәнелүе белән дә тәэмин ителгән.* Х.Миңнегулов. *Ярый әле һәр экипажга --- биш көнлек коры паёк бирелә, бу паёк аэродромга әйләнеп кайтканчы тукланып торырга таман гына булды.* Ф.Хуҗин

**ТУКЛАНУ** II *и.* Нормаль үсеш өчен кирәкле матдәләр алу процессы. *Бу бозык каннан ничек котылу юллары да медицина китапларында ачык күрсәтелмәгән. Һаман шул режим, дөрес туклану, дөрес яшәү, саф һава, имеш.* Ф.Бәйрәмова. *Тамырдан туклану. Катнаш туклану*

**ТУКЛА́У** *и. диал.* Су буенда хайваннарны су эчерү, шунда туплау урыны; туплавык. *Төш якынлый башлагач, көтүне су буена туклауга төшерәләр, --- дүрт-биш сәгатьсез туклаудан чыгармыйлар.* Г.Ибраһимов

**ТУКЛЫ** *и. диал.* Куй бәрәне

**ТУКЛЫК** *и.* 1) Тук I (*1, 3, 4 мәгъ.*) булу халәте. *Егетләрнең күзләрендә --- шул кызыл кирпеч икмәкләрнең шәүләсен күрәсең. Һәркайсының йөзе алдан ук туклык рәхәтен тоеп елмая сыман.* Х.Камалов

2) Калорияелелек, ашамлыкның туйдыручанлыгы. *Алма, диләр, алма ашыйлар, Нидер алма туклыгы? Бәхетлеләр рәхәт яши, Читен бәхет юклыгы.* Җыр

3) Азык-төлеккә, хуҗалык кирәк-яракларына байлык, муллык, иркенлек. *Туп уйнасаң, туклык булыр, таш уйнасаң, ачлык булыр.* Мәкаль. *Ничә ел күргән ачлыктан соң бу – беренче туклык бәйрәме. Келәтләрдә – ашлык, өй астында – бәрәңге.* М.Мәһдиев

**ТУКЛЫКЛЫ** *с.* 1) Туйдыра, ачыгуны бетерә һәм көч бирә торган; калорияле (ашамлык, азык тур.). *Төче коймак та әле кайнар көенчә, ә нииндидер үлән кушылган чәйнең хуш исе үк туклыклы һәм шифалы иде.* А.Тимергалин. *Хур кызы көтмичә, булганына шөкер итеп кенә яши белгән иргә назлы хатын, туклыклы аш, туйдырмас хезмәттән кала бәхетле булу өчен тагын ни кирәк соң?* В.Имамов

2) *биол.* Организмны туендыру өчен үзендә кирәкле матдәләр булган. *Дөньяда нәрсә булса да булыр – арыш бөртегенә кадәр туклыклы бүтән ризык булмас.* М.Мәһдиев. *Күбесе микробиологиядә микроблар үрчетү өчен туклыклы тирәлек сыйфатында кулланыла торган агар-агар һәм йод табу өчен чимал булып хезмәт итә.* Биология

3) Ашамлыкка, азык-төлеккә бай. *Берсеннән-берсе матур, ямьле, туклыклы айлар – июль, август, сентябрь.* А.Хәсәнов. *Илленче еллар. Әйбәт, туклыклы, ипиле тормышка халыкның өмете түгәрәкләнеп килгән чаклар.* Н.Кәримова

**ТУКЛЫКЛЫЛЫК** *и.* Азыкның, ризыкның туклыклы булу дәрәҗәсе; азык кыйммәте. *Сәгать сигездә ашарга китерәләр. Билгеле, аның туклыклылыгы юк. Гомумән, төрмәдә ачлык газабы даими.* Г.Әпсәләмов. *Силос өчен көнбагыш чәчелә, әмма көнбагышны күрән, үзән үләне белән бергә катнаштырырга кирәк. Шулай итсәң, туклыклылыгы, файдасы бермә-бер арта.* Х.Камалов

**ТУКЛЫКСЫЗ** *с.* Туйдырмый торган, калориясе аз булган. *Кайчандыр күңел түрендә йөргән романтика --- көн дә, торып, авыр, тупас көн итекләрне --- кию белән, тәмсез, туклыксыз тары боткасы, дөге боткасы чәйнәү белән алышынды.* Н.Фәттах

**ТУКЛЫКСЫЗЛЫК** *и.* Туклыклылыгы җитмәү күренеше. *Ашханәдәге азыкларның туклыксызлыгы*

**ТУКМАК** *и.* **1.** 1) Бер башы юан, икенче башы тотар өчен җайлап юнылган, нечкәртелгән агач кисәге. *Аталары бер каенга тукмакны бәйли дә, тукмак шак-шок сугып тора, үзе кайтып китә.* Әкият. *Сүснең җепселләре нечкәрсен өчен, килегә салып, саплы тукмаклар белән бик каты төяләр.* Х.Камалов

2) *диал.* Стена сәгатьләренең чылбырына авырлык өчен асыла торган тимер цилиндр; гер. *Тукта, сәгать ник йөрми? Ә-ә, тукмаклары идәнгә тәрәлгән икән бит.* Н.Әхмәдиев

3) *диал.* Чәкән. *Кукуруз тукмагы*

4) *бор.* Терсәктән алып йодрыкка кадәр ара озынлыгындагы үлчәү берәмлеге; терсәк, зираг. *Тукмак – терсәктән алып йодрыкка кадәр араның озынлыгын белдер[гән һәм] --- мануфактура, җеп белән сату итүче сәүдәгәрләр тарафыннан күп кулланылган.* Совет мәктәбе

5) *диал.* Ат муенындагы ярага камыт тимәсен өчен, камытка бәйләп куела торган калын киез кисәге

6) *күч. гади с.* Йодрык; йодрык белән кыйнау. *Эшче тукмаклары төшсә, Авыртыр калын җилкә.* Г.Камал. *Кунак егете исә, караңгыда төрле яктан килеп төшкән тукмакларга җавап бирә алмыйча, ике кулы белән башын тоткан.* Ф.Яруллин

7) *күч. гади с.* Бәла-каза, җәза; кыйналу. *Ул вафасыз дөньяда җил-яңгыр тимичә, мәрхәмәтсез урам тормышының камчысын да, тукмакларын да күрмичә --- үскән самими һәм тыйнак малай иде.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ. диал.* Кыска һәм куе. *Безнең тукмак яллы туры айгыр бар ич! Тоттым да менеп атландым мин моңа.* Н.Исәнбәт

◊ **Тукмак борын** Зур, җәенке борын. *Малайның кысыграк күзе белән тукмак борыны [әтисе] Сабир икәнен әллә каян әйтеп тора.* М.Кәримов. **Тукмак төшү** Берәр нәрсә өчен җәза күрү, авырлык килү. *Райкомга каршы сүз әйтеп булмый, тукмакның үз башыңа*

*төшүе бар ---.* М.Маликова. *Эт оясын кормасаң да, гараж ишеген ясамасаң да башына тукмак төшә.* Н.Хәсәнов

**ТУКМАКБАШ** *и. зоол.* 1) Карчыганың бер төре; *русчасы*: **подорлик большой**. *Тукмакбаш оясы*

2) *диал.* Чукмарбаш, бака маймычы. *Суда тукмакбашлар йөзә*

**ТУКМАКБА́Ш ҮЛӘНЕ** *и. диал.* Сарут, актамыр; *русчасы*: **пырей**

**ТУКМА́К ҖИЛӘК** *и. диал.* Җир җиләге

**ТУКМАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тукмаклау** (*1 мәгъ.*). *Киндернең тукмакланган өлешен җәйгә гына аска тартып торучы яшүсмер кызларның берсе әлеге дә баягы Миңниса икән.* Г.Бәширов. *--- ул арада мунча да өлгерде, мунчага керәсе ирнең, бала-чаганың күлмәк-ыштаннары күптән юылып, сырлы бәләк белән тукмакланган ---.* М.Мәһдиев

2) Тукмак формасын хәтерләтү. *Тукмакланган борын*

**Тукмаклана бару** Акрынлап барысы да тукмаклану

**Тукмакланып бетү** Барысы да тукмаклану, тукмакланган хәлгә килү

**Тукмакланып тору** Тукмак булып күренү

**ТУКМАКЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тукмаклау** (*2 мәгъ.*). *Явыз директор, берничә таза егетне яллап, егетне бик шәпләп тукмаклатканнан соң, Туктарга туган йортының бусагасына кайтып егылудан башка юл калмады.* Х.Ибраһим

**Тукмаклатып тору** Һаман, даими тукмаклату; әледән-әле, еш тукмаклату

**ТУКМАКЛА́У** *ф.* 1) Тукмак белән бертуктаусыз сугу, еш-еш бәрү; бәләкләү. *Кызлар кызу-кызу киндерләрен агартып бетереп, тукмаклап, сандыкларга җыеп --- куярга ашыгалар.* Г.Исхакый. *Егетләр кичә үк юып элгән күлмәкләрен тукмакларга, кызыл балчыкка каткан итекләрен юарга, майларга тотындылар.* Г.Сабитов

2) *күч.* Кыйнау; еш-еш сугу. *Сине тотып тукмакларга кирәк иде дә, булмый бит менә.* А.Тимергалин. *Бу тормышта --- үз урынын таба алмаган --- Малик, нишләптер, Маратны куралмый һәм аны җае чыккан саен тукмаклый иде.* Д.Гыйсметдин

**Тукмаклап алу** Җиңелчә генә тукмаклау. *Я, инде бер матур гына итеп киндер тукмаклап алыгыз.* Г.Камал

**Тукмаклап ату** *к.* **тукмаклап ташлау**. *Әле күптән түгел генә дә бер таксист, кеше утыртып юлга кузгалырга маташучы бер машина хуҗасын үз күз алдымда тукмаклап атты ---.* Безнең гәҗит

**Тукмаклап бетерү** Барысын да тукмаклау. *Без хәзер камалган ерткычны «тукмаклап бетерү» эшен дәвам иттерәбез.* Казан утлары

**Тукмаклап карау** Нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү өчен тукмаклау

**Тукмаклап ташлау** Тиз генә, җиңелчә генә тукмаклау; нык тукмаклау. *Җиңсә, бу таза ирнең көчсез баланы тукмаклап ташлавын хәтерләтәчәк, чөнки Грузия армиясенең куәтен Россиянеке белән чагыштырырлык та түгел.* Ватаным Татарстан. *Ә 41 яшьлек ир-атны танышы тукмаклап ташлаган.* Яшел Үзән

**Тукмаклап тору** Вакыт-вакыт яки һәрвакыт тукмаклау. *Без бит инде аны болай да эшендә түбәнәйттек. Кешене гел тукмаклап торып та булмый.* Г.Әпсәләмов. *Никадәр генә орышып, тукмаклап торса да, хыял-хисләргә чумган баланы тыя алмый шул инде әбисе: тәмле исләр аңкытып торучы төрле төсле карандашлар ахырына кадәр очланып бетә...* К.Җәмит

**Тукмаклап чыгу** Һәрберсен бербер артлы тукмаклау

**Тукмаклый башлау** Тукмакларга тотыну. *Виктор ташны ачу белән җиргә бәрә дә чүкеч белән тукмаклый башлый.* Г.Сабитов. *Исерек Миннәхмәт савым сыерлары фермасында сәнәк сабы белән сыртын гадәтенчә тукмаклый башлагач, ярсыган горур Акъял, камытыңгырчак бауларын өзеп, тәртәләрен каерып, качып китте.* В.Имамов

**Тукмаклый тору** *к.* **тукмаклый бирү**. *Әбисе тукмаклый тора, ә ул... очлавын белә.* К.Җәмит

**Тукмаклый төшү** Тагы да ныграк тукмаклау

**ТУКМАКЛАШУ** I *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тукмаклау**. *Кызлар, киндерегезне тукмаклашырга, кочаклашырга, уйнашырга, җырлашырга --- килеп җитәрбез.* К.Тинчурин

2) *күч.* Йодрык белән кыйнашу, сугышу. *Әмма егетләрдән аермалы буларак, кызлар, бар дөньяларын онытып, бер-берләрен аямыйча, ахыры турында кайгыртмыйча тукмаклаша ---.* А.Галимов

**Тукмаклаша башлау** Тукмаклашырга тотыну

**Тукмаклашып алу** Җиңелчә генә тукмаклашу. *Балалар бер читтә нәкъ сабан туендагы кебек йөгерештеләр, көрмәкләштеләр, кычкырыштылар, хәтта бер-икесе тукмаклашып та алды.* Ә.Фәйзи

**Тукмаклашып китү** Кинәт тукмаклаша башлау

**Тукмаклашып тору** Вакыт-вакыт яки һәрвакыт тукмаклашу

**ТУКМАКЛАШУ** II *и.* Кыйнаш, сугыш. *Шушы бәргәләшүдән соң кемнең дә булса үпкә тотканын, тукмаклашуны начар итеп искә алучыны күрмәссең.* А.Хәсәнов

**ТУКМА́К СӨЯГЕ** *и. анат.* Җилкә сөяге

**ТУКМА́К ТӘРӘЗӘ** *и. диал.* Авыл өйләрендәге мичкә урнаштырылган казан ягына караган кечкенә тәрәзә, ян тәрәзә

**ТУКМАКЧЫЛ** *с. сир.* Кыйнашырга яратучан. *Яман ат – сукмакчыл, яман кеше – тукмакчыл.* Мәкаль

**ТУКМАЛА́У** *ф. диал. к.* **тукмаклау**. *Каядыр авыл кызларының киндер тукмалаганнары ишетелә.* С.Җәлал

**ТУКМАР** *и.* Кыска юан һәм авыр таяк. *[Концлагерьда] коелган кул богаулары, резина тышчалы тукмарлар [бар иде].* Ш.Рәкыйпов

**ТУКМА́У** *ф. сөйл.* 1) *к.* **тукмаклау** (*1 мәгъ.*). *Кызлар киндер тукмаганны безнең китап бик мактый.* Г.Камал. *[Гөлбану] киндер сукты, --- киптереп агартты, аннан җәйге кичләрдә иптәшләре белән җыелып тукмадылар.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Нык сугып кыйнау; дөмбәсләү. *Берничә көннән соң, ул һич көтмәгәндә, кулында таягы юк чакта тотып алдык та үзен бик әйбәтләп*

*тукмап җибәрдек.* В.Нуруллин. *Бер авылда аны кендекләр белән тукмап кайтардылар инде.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Дошманга көчле һөҗүм ясау, сизелерлек зыян ясау. *Безнекеләр Сталинградта немецларны бик каты тукмаганнар, ди.* Т.Гыйззәт. *Ак финнарны күптән түгел генә тукмадык дип беләбез.* А.Тимергалин

**Тукмап алу** *к.* **тукмаклап алу**. *Сезнең сүзегезгә ышанып, үземне харап итә яздым бит. Кая әле, булмаса, бер үзегезне тукмап алыйм.* Т.Гыйззәт. *Торак егетләре, Толикның хәленә кереп, Миләүшә тирәсендә чуалучы берәр курсантны тукмап алырга да каршы түгелләр.* А.Хәсәнов

**Тукмап ату** *к.* **тукмап ташлау**. *Менә ул җиңеллек эзли, юк, таба алмый; тагы эчә, ачуы кабара, кемнедер тукмап атасы килә ---.* Х.Ширмән. *Алар төн уртасында вагоннарыннан чыгып, --- шактый салмыш өч урыс егетен тукмап атканнар.* Татарстан яшьләре

**Тукмап бетерү** Барысын да тукмау; нык тукмау. *Кешелекнең иң явыз дошманын – фашизмны – үз өнендә тукмап бетерер өчен ашкынып алга баручы совет сугышчылары арасында Газинурның сугышчан дуслары да бар.* Г.Әпсәләмов

**Тукмап карау** Сынау өчен тукмау. *Харис чыннан да еламый иде, шуның өчен аны зуррак малайлар мәктәптә ничә тапкыр тукмап карады: елатырга тырыштылар.* З.Мурсиев

**Тукмап ташлау** Тиз арада, бик нык тукмау. *Шуңа күрә дә ул, ачуы килеп, я үзенең яшьтәшләрен тукмап ташлый, я булмаса ат атланып чаба, уктан ата, сөңге чөя иде.* Н.Фәттах. *Егет үзен тукмап ташларга җыенулары хакында серне чишмәде.* Т.Галиуллин

**Тукмап тору** Гел, еш, даими яки хәзерге вакытта тукмау

**Тукмый башлау** Тукмарга тотыну. *Авылына кайтып керү белән, исәнләшергә дә онытып, адәмнәрне мәйданга җыйды да курай уйнарга кереште. Ләкин, рәхмәт урынына Чәлбәкне эт итеп тукмый башладылар.* Р.Батулла. *Бер-ике күнегүдән соң туктаучылар да табылды: күн йодрык белән башкаларга кизәнгәндә генә кызык ул, ә үз башыңны тукмый башласалар, бер дә рәхәт түгел икән.* К.Кәримов

**ТУКМАШУ** I *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тукмау**

2) Кыйнашу, сугышу. *Алар эшкә көн аралаш кына йөриләр, эчәләр, тукмашалар.* Р.Кәрами

**ТУКМАШУ** II *и.* Кыйнаш, сугыш

**ТУКМЫЙ** *и. диал.* Чукмарбаш. *Күлдә вак тукмыйлар йөзә*

**ТУКРАН** *и. зоол.* Тукранкошлар семьялыгыннан үткен, озын томшыгы белән агачның кабыгын тишеп, үзагачтагы кортларны чүпләп туклана торган урман кошы. *Дөньяда тукраннар бик күп: чуар тукран, ак аркалы, яшел, кара, чал тукран һәм башкалар.* К.Тәхау. *1933 елларда исә әле анда тилгәннәр, урман тавыклары, төлке, куян, бүре, ябалаклар, күке, тукран һ.б. җан ияләре тулып ята иде.* М.Мәһдиев

◊ **Тукран тәүбәсе** Гел бозыла торган тәүбә; әйткән сүздә тормау, вәгъдәсезлек. *Эчмим дип сүз бирде, сүзе тукран тәүбәсе булып чыкты.* Х.Камалов. *Биргән вәгъдәләре дә тукран тәүбәсе генә булмас, Гүзәлия ханым яши торган йорттагы кешеләр дә, балалар бакчасындагы сабыйлар да суга башка тилмермәсләр, дигән өметтә каласы килә.* Л.Локманова

**ТУКРА́Н БАБАЙ КАРЧЫГЫ** *и. этн.* Авызына чыралар капкан, таякка таянган «әби»нең балалардан каз ите таләп итеп (балалар каз ите урынына «әби»гә нәрсәдер бирәләр), аларга сөякләр кайтаруы, үз әйберләрен танымаган балаларны «бабай»га иптәшлеккә калдыруыннан гыйбарәт уен. – *Туктук итә – кемдер ул? – Тукран бабай карчыгы.* Такмак

**ТУКРАНБАШ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан өч яфрагы да бер сабактан чыккан һәм чәчәкләре шарсыман булган үлән үсемлек; клевер. *Мин алсу чалмалы тукранбаш өзеп, аның тәмле суын суырырга тотындым.* Г.Бәширов. *Ә сазлыкның өстен ак клевер, ягъни тукранбаш сарган.* А.Хәсәнов

**ТУКРА́Н ПЕЧӘНЕ** *и. диал. к.* **тукранбаш**

**ТУКРА́Н ТУБАЛАГЫ** *и. бот.* Шомбиячәләр семьялыгыннан итләч сабаклы, кабырчыксыман яфраклы, башак формасындагы кып-кызыл чәчәкле бер, ике яки күпьеллык тәбәнәк чүп үләне; шомбия; *русчасы:* **заразиха**

**ТУКРА́У** *ф. диал.* Туктау, тукталып калу (гадәттә юклык форм.). *Кыл сыймый, кисап тукрамый.* Әйтем

**ТУКСАК** *с.* Аксак (гадәттә *аксак* сүзе белән кулланыла). *Күп куйда аксак та була, туксак та.* Мәкаль. *[Ирне] алмадылар. Туксак ул.* Д.Зөбәерова

**ТУКСАН** *сан* Тугыз дистәдән гыйбарәт сан; шул санны, аның микъдарын, цифрын белдергән атама. *Шулвакыт патшаның чәч-сакал кыручысы – туксан яшьлек бер карт – падишаһның аяк астына ташлана ---.* Әкият. *Казан безгә ерак түгел, нибары туксан километр гына.* В.Нуруллин

◊ **Туксан алтынчы пробалы** 1) Югары сыйфатлы. *Сез – туксан алтынчы пробалы адәми зат – аның урынында булсагыз, утыз ел буе артыгыздан калмый үкчәгезгә басып йөргән шушындый гүзәл хатыннан баш тартыр идегезме?* Д.Салихов; 2) Чит сыйфатлар кушылмаган, саф. **Туксан тугыз** 1) Бик күп. *Көтә-көтә көтек була язгач, көннәрдән бер көнне --- башына туксан тугыз маймыл рәсеме төшкән кепка кигән бер бәндә килеп керде боларга.* Ф.Яруллин. *Туксан тугыз мәртәбә комплимент әйтсәләр, йөзенчесендә ул хатын-кыз хыянәт итми тыелып кала алмаска мөмкин.* М.Галиев; 2) *кимс. к.* **туксан тугызлы**. **Туксан тугыз ата баласы** Берәр җирдә тупланган балаларның төрле булуы турында. *Минем дачада гел йолкыш вак-төяк балачага. Туксан тугыз ата баласы. Детдом дигән нәрсәләрен җәй көне шунда күчерәләр.* Ш.Камал. **Туксан тугызлы** *кимс.* Җиңел акыллы, юләр сыман. *Кырда ялгыз йөргәнлектән, авыл балалары арасында Шәйдулланы туксан тугызлы дип исәпләүчеләр дә байтак иде.* М.Мәһдиев

**ТУКСАНЛАП** *сан* Чама белән, якынча туксан булуны белдергән чама саны. *Әти белән әнидән кала, алар чыгарылышында шундый ук тагын алты*

*пар бар әле. Туксанлап бала өчен, бер яктан карасаң, бу күп тә түгел сыман.* Л.Локманова. *Туксанлап гармунчы белән сөйләштем, язмалар да алып кайттым.* Ватаным Татарстан

**ТУКСАНЛА́У** *ф.* Эшләү, итү (*үз туксанын туксанлау* гыйбарәсендә генә кулланыла). – *Ә кермәгәч, нигә үзең алып чыкмадың? – дигән Зәйнетдин абый, һаман үз туксанын туксанлап.* В.Нуруллин. *«Аның баласы» дип, үз туксанын туксанлап тик тора...* Г.Гыйльманов

**ТУКСАНЫНЧЫ** *сан* Санаганда, туксан урынында килә торган тәртип санын белдерә. *Егерменче йөзнең туксанынчы еллары азагында ил корабы төпкә баткач, адәм баласы кыйбласын җуйды.* Н.Гыйматдинова. *Җилфердәп, җәлт-җәлт килеп йөргән газиз әнисе дә туксанынчы яше белән бара.* Я.Гарипова-Әбдрәхимова

**ТУКСАНЫШАР** *сан* Һәркемгә, һәрнәрсәгә бертигез күләмдә туксан булуны белдергән бүлү саны. *Ә борынгы заман кешеләре кебек, алай сиксән, туксанышар ел торырга безгә кая инде?!* Г.Толымбай. *Туксанышар битлек өч дәфтәрне тутырдым инде, тик әлегә очы-кырые күренми.* Ф.Яруллин

**ТУКСЫНУ** *ф.* 1) Аз ашка да канәгатьләнү, тую

2) Туклык тою, үзен тук дип санау. *Тәрәзәм төбе гөлҗимеш, ашыйсым килми туксынып.* Җыр

**ТУКСЫРА́У** *ф. диал.* Тую, бизү. *Балалар чыр-чуыннан туксырау*

**ТУКСЫРТУ** *ф. диал.* Туйдыру, биздерү. *Бәрәңгене көн саен ашасаң туксырта шул*

**ТУКСЫРУ** *ф. диал.* 1) Ашап тую, бик аз ашап та канәгать булу

2) Үтләү, бизү

3) *к.* **туену** (*2 мәгъ.*). *Көзге яңгырлар белән туксырган җир суны бөтенләй сеңдермәде.* А.Гыйләҗев

**ТУКТАЛУ** *ф.* 1) Барган җирдән хәрәкәтне вакытлыча өзү; хәрәкәтсез калу. *Ике юл чатына килеп җиткәч тукталып калдым.* Н.Хәсәнов. *Бер мәлгә тукталып, башын да күтәрмичә өйалды баскычын юучы хатынына озак кына карап торды ул.* А.Мансуров

2) Эштән вакытлыча бүленү, туктау. *Эшчеләр [эш ташлады], фабрикалар, тегермәннәр тукталды.* Ш.Мөхәммәдев. *Кибетнең түбәсе ябылган, тәрәзәләре куелган, шуннан соң эш тукталган.* Ф.Садриев

3) Үз эшен, шөгылен вакытлыча өзеп тору, бүлү. *Беркөнне егетләр, металл коюдан тукталып, ял итәргә утырганнар иде.* Н.Хәсәнов. *Пәттери гармунда уйный-уйный да тукталып бер сүз әйтә ---.* Ф.Җамалетдинова

4) Чыкмый башлау, ябылу (вакытлы матбугат тур.). *«Фикер», Уклар» һәм «Әлгасрелҗәдит» журналлары тукталганын ишеткәч, Сәйдәш бабай шатлыгыннан --- ура кычкырган.* Ш.Мөхәммәдев. *Газета тукталгач, Х.Ямашев, Тукайдан ике генә ай элек, Казанга әйләнеп кайта.* И.Нуруллин

5) Берәр эштән яки хәрәкәтләнүдән үз-үзен тыеп калу. *Килгән шәпкә атлап үтим дисәм, аяклар тотлыгып калды. «Ярамый!» дигән сизенүгә сәерсенеп, шып тукталдым.* Ш.Галиев. *Фашистларның Көнчыгыш Пруссия группировкасы тар-мар ителүгә күп калмады, һәм алар, үзләре беткәндә, бернәрсә алдында да тукталып калмаячаклар.* Ф.Хуҗин

6) Өзелү, тыну, тәмамлану, бетү, дәвам итмәү (хәрәкәт, үсеш, агым һ.б.ш. тур.). *Шундый зур куанычтан кинәт йөрәгем тукталгандай булды.* Н.Фәттах. --- *«Масра бабай килгән» дигән хәбәр --- таралган көнне урамда уеннар туктала ---.* М.Мәһдиев

7) Берәр урында тоткарлану, тукталыш, тыныш ясау (эш-хәрәкәт тур.). *Мишә буенда тукталып, Черчилльне тугарып, берәр сәгать ашатыпэчереп, ял иттереп алырга булдык.* В.Нуруллин. *Сергеевның Чаллыда тукталып торырга исәбе юк иде, күрәсең.* В.Имамов

8) Берәр урынга, берәр кешегә вакытлыча торырга, кунарга, ял итеп, ашап-эчеп чыгарга керү. – *Алданрак килеп төшүебез өчен гаеп итмәсеннәр дип, Хатирә, сезгә тукталдык инде, – диде ул.* Г.Әпсәләмов. *Колхоз аларны бушлай ашата, алар тукталган фатир хуҗаларына шулай ук колхоздан хезмәт көне язып барыла иде.* В.Нуруллин // Үзенең юлын, сәяхәтен берәр төрле эш, сәбәп белән теге яки бу урында өзү, тоткарлау. *Узып барышлый (документлар алыр өчен) Мәскәүдә тукталдым.* Г.Кутуй. *Анкарада бер кичкә тукталдым. Монда минем җәйге сәяхәтемдә танышкан дин укытучысы Али бәй Татар, профессорлар Гайсә белән Фатыйма ханым --- кебек дусларым бар.* Р.Батулла

9) Караш, игътибар, фикер һ.б.ш.ны берәр җанлы-җансыз нәрсәгә юнәлдерү. *Аның уйлары, ерак-еракларга китеп, яңадан шушы авыр, хәсрәтле чынбарлыкка кайтып төшәләр, ул инде йөз, мең тапкыр кабатланган бер фикергә туктала иде ---.* Г.Әпсәләмов. *Газета-журналлар актарып утырганда, күзе бер игъланга тукталды.* И.Нәбиуллина

10) Сөйләгәндә, нәрсәне дә булса тикшергәндә, тасвирлаганда, игътибарны билгеле бер нәрсәгә юнәлтү, басым ясап узу. *Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына атап язылган тагын бер әсәргә тукталып китим.* Р.Батулла. *Аннары хәл-әхвәл белеште, гадәтенчә, күңелгә ятышлы итеп кенә кеткелдәп алды, төп йомышка тукталды.* Ф.Баттал

11) *күч.* Җанлы-җансыз нәрсәләр арасыннан берәрсен сайлап алу. *Күңелдән байтак сайлап баргач, ул ике украин егетенә тукталды.* И.Гази

12) *күч.* Теге яки бу караргa, фикергә килү

**Туктала башлау** Тукталырга тотыну. *Ул арада берәм-берәм комбайнчылар да әбәткә туктала башлады.* Г.Бәширов. *Шәһәрдә Зөфәрне белүчеләр күп, я берәрсе очрап, янында туктала башлар.* Ә.Еники

**Туктала бирү** Тукталуын дәвам итү. *Зөфәр, туктала биреп, Рәшидәне алгарак уздырды.* Ә.Еники. *Малай, йөгергән җиреннән туктала биреп, очкан кепканы тотмакчы булды.* З.Зәйнуллин

**Туктала төшү** Бераз тукталу. *Боларга каршы, яшь айгырны уйнатып, кулына озын корык тоткан бер казакъ килә иде. Җитәр-җитмәс туктала төшеп, сәлам бирде.* Г.Ибраһимов. – *Миңа,*

*Мирсәет абый, кайтып та җиттек, – диде Фатыйма, туктала төшеп, һәм икенче каттагы ут алынган ялгыз тәрәзәгә ымлады.* Р.Мөхәммәдиев

**Тукталып алу** Кыска гына вакытка тукталу. *Баш табиб түр почмакта тезен чәнчеп утырган чандыр карт янында тукталып алды.* М.Маликова. *Нindидер бер тавыш чыңлап тора. Тукталып ала да тагын сузып-сузып кычкырта.* Г.Гыйльманов

**Тукталып калу** Кинәт тукталу. *Кораб уңга-сулга селкенгәләп тора да тукталып кала.* Әкият. *Тигез юлдан чабып барганда, кинәт, упкын буена килеп чыккандай, шып тукталып калдым.* В.Нуруллин

**Тукталып китү** Эш яки сүз барышында тукталу. *Килен төшү вакыйгасына әз генә булса да тукталып китмәсәм, хикәям тулы булмас кебек.* Ф.Яруллин. *Шуның өчен дә бу мәкаләдә мин әнә шул язмаларга җентекләбрәк тукталып китүне максат итеп куйдым.* И.Газиев

**Тукталып тору** Вакытлыча тукталу; хәзергә тукталу. *Бик аз гына тукталып торды, аннары, тәвәккәлләп, капкадан эчкәре атлады.* Ә.Еники. *Кояш яктысында балкып яткан киң аланда күңелле шау-шу әз генә дә тукталып тормады.* Н.Фәттах

**Тукталып узу** *к.* **тукталып китү**. *Совхоз үзәгендәге культура йортына кайткач, Арсланов яңа сортлар белән эшләү тәҗрибәсенә дә киң тукталып узды.* Ф.Садриев. *Бикчуринның «Табылдык» хикәясенә дә тукталып узасы килә.* Р.Миңнуллин

**Тукталып үтү** *к.* **тукталып китү**. *Каргалы халкының зыялы катлавыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә шактый. Шуларның берничәсенә генә тукталып үтик.* М.Маликова. *Шәхси үсеш юлы турында күпмедер сүз булды инде, җәмгыятьнекенә дә тукталып үтик.* Р.Сафин

**ТУКТАЛУСЫЗ** *рәв. к.* **туктаусыз**. *Җәенке ботаклы шул тут агачлары күләгәсендә бераз ял итеп алу кызыгырлык нәрсә булса да, мөһаҗирләр юлны берниндн тукталусыз дәвам иттеләр.* М.Галәү. *Саркисянның ачык капкасыннан берниндн тукталусыз корыч ат килеп керде.* А.Нәҗми

**ТУКТАЛЫШ** *и.* 1) Эш-хәрәкәттән вакытлыча бүленеп, тукталып тору; тикторыш. *Тукталыштан абзый шул чакта туеп, Китте юлдан, кулларын артка куеп.* Г.Тукай. *Куян эзе Яке елгасына төшеп китте, куян тукталыш ясаган, арт аякларына басып, тирә-юньгә күз салган.* Р.Газиз

2) Сөйләмне вакытлыча бүлү, өзү; пауза. *Сәет шунда тыны кысылган кешедәй тукталыш ясады һәм, тавыш тембрын үзгәртеп, дөресе, кырыслык өстәп сорап куйды: – Мин нишләргә тиеш?* Т.Галиуллин. – *Әйтсәм әйтим инде, җәмәгать, минем Гөләемне тәү мәртәбә күрүем дә әнә шул төштә күрү шикелләрәк булды, – дип әйтеп, Билал мәгънәле генә бер тукталыш ясап, аннары ары таба сөйләп китәргә уйлап тора иде ---.* М.Вәлиев

3) Билгеле маршрут белән йөри торган транспортның туктап тору урыны; транспорттан төшү яки аңа утыру урыны. *Трамвай тукталышына җитәрәк, Кифая Зәйтүнәне чакырып алды.* М.Маликова. *Урамда караңгы эленгәндә, егетләр, Камил белән Дилбәр яшәгән йорттан чыгып, тукталышка таба атладылар.* Н.Хәсәнов

4) *сөйл.* Шул урыннар арасындагы юл озынлыгы. *Светкаларга барып кайтырга микән? Ерак түгел бит, ике генә тукталыш.* Л.Ихсанова. *Бибисара ишеткән иде: озын тукталышларда башкисәрләр «челноклар»ны капшый икән.* Н.Гыйматдинова

5) Кая да булса барганда, сәяхәт иткәндә (куну, ял итү һ.б.ш. максатлар белән), юл уңаендагы берәр урында вакытлыча тоткарлану. *Ике йөз чакрым араны без дүрт тукталыш ясап йөздек, ягъни дүрт җирдә тукталып, кунып-төнеп ятып, палатка-тирмәләр корып, казан асып.* Р.Фәйзуллин. *Зуррак шәһәрләрдә озаграк, ә кечерәк торак пунктларда кыска вакытлы тукталышлар ясап барса да, безнең эшелон күз бәйләнгәндә инде Пенза вокзалында иде.* Ф.Хуҗин

**ТУКТАЛЫШЛЫ** *с.* Тукталышы (*3 мәгъ.*) булган. *«Казан» тимер юл вокзалыннан «Кояшлы шәһәр» микрорайонына кадәрге 32 тукталышлы араны трамвай 58 минутта үтә.* М.Низаметдинова

**ТУКТАЛЫ́Ш НОКТАСЫ** *и. физ.* Механизмнарда шатунның ике кырый торышта туктап калган ноктасы; *русчасы:* **мёртвая точка**

**ТУКТАЛЫШСЫЗ** *с.* **1.** Тукталышлары булмаган. *Юк, миңа андый тукталышсыз ерак сәфәр кирәк түгел.* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Туктамастан, туктамыйча. *Рак тантана итте, рак Фәкилә апаны берниндн тукталышсыз үлемгә табан сөйрәде.* Г.Рәхим. *Тик нәкъ менә шул минутта трамвай, тизлеген арттыра барып, инде берниндн тукталышсыз, караңгылыкка очты.* Т.Кәримов

**ТУКТА́МАСТАН** *рәв.* 1) Туктаусыз, бер дә туктамыйча, өзлексез. *Менә унике ел инде минем башым көнентөнен бер генә минут туктамастан чыңлап, шаулап тора.* Г.Бәширов. *Шул көннән алып өч ай буе туктамастан сорау алулар, кыйнаулар, типкәләүләр, мәсхәрәләүләр китте.* З.Зәйнуллин

2) Туктарга өлгергәнче, туктап җиткәнче, туктамас борын. *Атлар туктамастан арбадан сикереп төшеп, Айгөл атасына каршы йөгерде.* И.Хуҗин

**ТУКТАР** *и.* Кайбер тотрыклы сүзтезмәләр составына кергән ялгызлык исеме

◊ **Туктар кабагы итү** Берәр урынга еш кереп, гадәттә идәнне таптап йөрүне яратмаганда әйтелә

**ТУКТАТКЫСЫЗ** *с.* Туктатып булмый торган; бик көчле. *Туктаткысыз һөҗүм*

**ТУКТАТКЫЧ** *и. тех.* Билгеле бер торышка җиткәч, машинаның берәр блогын, агрегатын автомат рәвештә эшләүдән туктата торган механизм; *русчасы:* **останов**. *Ә хәзер, күрәсең, шундый вакыт җитеп килә ки, һәр механизмга туктаткыч, тормоз кую зарур.* А.Тимергалин

**ТУКТАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **туктау** (*1–3 мәгъ.*). *Ярый, Гыйшкыя, бу турыда сүзне туктатыйк, беркая да китмисең, вәссәлам.* Ф.Яруллин. *Кызыл Армия Мамадыш белән Малмыж*

*арасында, Нократның бирге ягында ныгытмалар корып, дошманны туктатырга әзерләнде.* Р.Мөхәммәдиев

**Туктата башлау** Туктатырга тотыну. *Әни дә, минем арттан калмаска тырышса да, арыды, мине еш-еш: «Кызуланма! Кызуланма!» – дип туктата башлады.* Г.Исхакый

**Туктатып алу** *к.* **туктатып тору**. *Әби беразга гына өстәл өстендәге матур итеп төрелгән зур төргәккә карашын туктатып алды.* Д.Бүләков

**Туктатып карау** Туктатырга тырышу. *Минә хәзер уянды, ерылган буаны туктатып кара, ташкынны кире буып кара!* Т.Гарипова. *Кырт, кисәк кенә тукталу ай-һай авыр, туктатып кара таудан түбән бар шәпкә тәгәрәгән ташны.* К.Кара

**Туктатып кую** Тиз генә яки алдан туктату. *– Алай дип әйтеп булмый... – диде Рәфис һәм, телен йоткан сыман, башлаган сүзен туктатып куйды.* И.Хуҗин. *Андый чакта тәҗрибәле эшчеләр станокларын туктатып куялар да шунда утырып кына бераз ял итеп алалар.* Р.Фәизов

**Туктатып тору** Берникадәр вакытка, вакытлыча туктату. *Үзәк вакытлыча барлык өйрәнүләрне туктатып торырга куша.* Г.Әпсәләмов. *Әни, әйдә, җитди сүзләрне туктатып торыйк әле.* М.Маликова

**ТУКТА́У** *ф.* **1.** 1) Хәрәкәтне өзү, бүлү, бетерү, хәрәкәтсез калу. *Олы урамнан җиңел генә юыртып килгән бер атлы аларга җитәрәк читкәрәк чыкты да кинәт туктады.* М.Хәсәнов. *Без палаткалар корып урнашкан түгәрәк аланга җитәргә ике-өч йөз метрлар кала, Зөлфия шып туктады.* А.Хәсәнов

2) Берәр төрле эшне эшләүдән, башкарудан тукталу, үз-үзен тыю, чикләнү. *Мәрдәншә агай, үзенең бер гаепсез кешеләр алдында кызып китүенә уңайсызланган шикелле, шундук Инсафны сүгүдән туктады.* Н.Фәттах. *Гаҗәп, сабый читкә тартылмады, елавыннан туктап, Зәйтүнәнең муен мәрҗәнен тотып-тотып карый башлады.* Г.Галиева

3) Эшне, шөгыльне вакытлыча өзү, бүлү. *Бия ашавыннан туктады.* Г.Бәширов. *– Яратам әсәрләрдәге гыйбарәләрне, – диде Гөлмирә, язуыннан туктап ---.* Р.Кәрами

4) Хәрәкәт, үсеш, агыш, авыру һ.б.ш. өзелү, бетү, дәвам итмәү, басылу. *Яңгыр туктагач та, кешеләр, куанышып, өйләренә ашыктылар, учакларын тергезеп җибәрделәр.* Н.Фәттах. *Аның машинада барганда үтереп сызлаган тәне Әлфред күтәреп алуга авыртудан туктады.* Ф.Яруллин

5) Нинди дә булса басма чыкмый, нәшер ителми башлау. *Хәзер Һади шигырь язмый, ул гадәтне ташлаган. Ахры, газета туктагач, Илһам килми башлаган.* М.Җәлил. *Татар өчен газиз «Казан», «Татарстан» исемнәрендәге милли журналлар чыгудан туктады.* Р.Фәйзуллин

6) Чит җиргә килгәч, вакытлыча берәр урынга яки берәр кешегә торырга, ял итәргә, кунарга керү; төшү. --- *Казанга бардым, үзәк мәйданда күтәрелгән мәһабәт «Татарстан» кунакханәсендә туктадым.* С.Сабиров. *Рәхимшаның танышына туктадылар.* Р.Газиз

7) Сөйләгәндә, берәр нәрсәне тикшергәндә, тасвирлаганда, аның кайсы да булса өлешенә игътибарны юнәлтү, басым ясау. *Мин бу дауның үткән тарихына, бездән алда булган чорына туктап тормыйм.* Һ.Такташ

8) Боерык фигыль формасында янау, куркыту, кисәтү төсмерен белдереп килә. *– Безнең капкага билге ясап йөрүче минә кем икән. Тукта әле, мин сине акылга утыртыйм, – дип уйлады Мәрҗәнә ---.* Әкият. *Тукта, күрсәтер әле ул аңа үзенең кулларын!* Ә.Еники

9) Боерык фигыль формасында нинди дә булса эш яки хәрәкәт вакытында аны кинәт акрынайту яки бөтенләй өзүне таләп итүне белдереп килә. *– Тукта, ул бит кешегә бирәсе акча! – дип кычкыра Альфред һәм аның артыннан ташлана.* Ф.Садриев. *Урман авызындагы ваграк агачларга җиттем дигәндә генә: «Тукта, атам!» – дигән катгый боерык яңгырады.* Ә.Әминев

10) Боерык фигыль формасында булган җирдән китмәүне, шул урында калуны таләп итүне белдереп килә. *– Тукта инде, юләр, – дип, хатыны, итәгеннән тартып, урынына утыртты.* Р.Вәлиев. *Тукта, Гөлназ, бер генә минутка тукта әле!* И.Нәбиуллина

11) Боерык фигыль формасында берәр нәрсә эшләүне ташларга, ни дә булса эшләүдән баш тартырга өндәп әйтүне белдереп килә. *– Тукта, сиңа гына димәгән, җитәр! – дигән булып --- тагын берсе кочаклап сәкегә аударды да кайнар иреннәре белән үбәргә тотынды.* Г.Бәширов. *– Тукта, үтерәсең бит малайны! – диде ул, табагачы белән кизәнеп.* В.Нуруллин

12) Боерык фигыль формасында ашыкмаска, сабыр итәргә өндәп әйтүне белдереп килә. *– Туктагыз, тукта, ашыкмагыз, – диде зәңгәр танау, – моннан тагын бер-ике ярты алыйк, вагонда аларны кагарбыз* ---. Ф.Яруллин. *Телевизорны сүндерергә үрелгән Хәмидулланы Биктимер тыйды: – Тукта, сабыр ит, карыйк әле.* Д.Бүләков

13) *күч. к.* **тукталу** (*12 мәгъ.*)

**2. тукта, туктале, тукта әле** *ы. функ.* 1) Берәр нәрсә искә төшкәндә, берәр яңа уй-фикер туганда, шул фикер белән эш итәргә уйланганда әйтелә. *Тукта әле, безгә җыенга килүендә шул егет турында нидер сөйләде түгелме соң әби...* Г.Галиева. *Тукта, килешенә суыткычтан яраткан пепси-коласын алып куйыйм әле.* Н.Гыйматдинова

2) Гаҗәпләнүне яки берәр нәрсәдән ризасызлыкны белдерә. *Җаббар икәнен тануга, күңеленнән: «Тукта әле, бу аның сыеры ич. Нигә китерде икән ул аны?» – дигән уй узды.* Н.Хәсәнов. *Тукта, тукта, ул бит әнисе белән дә очрашырга теләми.* Ф.Садриев

**Туктап алу** Кыска вакытка гына туктау. *Дөнья Кәшфине байтак туздырды. Күрәсең, аз гына туктап алырга, капремонт ясарга кирәктер.* М.Мәһдиев. *Юлда бик матур урман аланына җиткәч, син: – Карагыз әле, нинди шәп алан, әллә бераз туктап алабызмы? – дидең.* Ф.Яруллин

**Туктап калу** *к.* **туктап кую**. *Флүр Сәхәбиевич, кызны көчле кулларында тоткан хәлдә, бүлмә уртасында туктап калды.* Р.Кәрами. *Кайчы асылган гер өстәлгә төшеп тәрәлә дә, вакытны керт-керт кискәләгән сәгать теле туктап кала.* М.Галиев

**Туктап китү** Юл уңаеннан туктау, тукталыш ясау. *Нигъмәтинең түбәндәге сүзләре бирелә: «Безнең юл»ның биш елы тулганда, каләм гаскәренең матур әдәбият армиясенә бераз туктап китсәк, урынсыз булмас.* Һ.Такташ. *Киткәндә генә, Казанга туктап китәргә мөмкинлек бирәчәкләр бугай.* М.Җәлил

**Туктап кую** Кинәт, кисәк туктау. *Җитмәсә, йөрәк тигез типми: бер-икене тибеп ала да китә дулап, китә дулап, бераздан туктап куя, аннары яңадан аралаш тибә башлый.* Ф.Тарханова. *Ләкин ике-өч минут үткәч, мотоциклның моторы да туктап куйды.* И.Хуҗин

**Туктап тору** Туктаган хәлдә булу; вакытлыча туктау. *Кызлар туктап торган арада, без, егет булып килүчеләр, алар белән уйнап алдык ---.* Г.Бәширов. *Азан әйткәндә, чишмәләрнең дә агудан туктап торуы хак икән.* А.Хәлим

**Туктап узу** *к.* **туктап китү**. *Казанга, Башкортстанда туктап узып, шушы максатта барлыкка килгән яңа оешманың «бикәсе», Төркия вәкиле Шинәл Бал килде.* Татарстан яшьләре

**Туктап үтү** *к.* **туктап китү**. *Башкорт журналистлары төркеме, Эстониядән, Салават Юлаев тоткынлыкта газап чиккән урыннардан әйләнеп кайтышлый, кабат Казанда һәм Минзәләдә туктап үтәчәкләр.* Татарстан яшьләре

**Туктый бару** Акрынлап туктау. *Монда керәшен татарларын да күздә тотсак, русның беренче карашка специфик реалия исемнәре булып тоелган күп кенә сүзләре реалия исемнәре булудан туктый бара.* Р.Йосыпов

**Туктый башлау** Туктарга тотыну. *Арттан килгән атның туктый башлавы булды, аны төрле яктан йөгерешеп килгән әбиләр, җиңгиләр сарып алды.* Г.Бәширов. *Арттан килүчеләр дә, алдагыларга якынлашып, шулай ук туктый башладылар.* Н.Фәттах

**ТУКТАУСЫЗ** *рәв.* **1.** Берөзлексез, туктамыйча, тоташтан. *Тәрәзә пыяласы туктаусыз зыңгылдап тора.* М.Галиев. *Утардагы атлар картның туктаусыз буылып ютәлләвенә, әледән-әле үзалдына сөйләвенә дә күнеккәннәр инде.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берөзлексез дәвам иткән, туктамый торган

2) Даими янаган, йөреш ясаудан үзгәрми торган. *Ул вакыт каралар, туктаусыз шах биреп, уенны тигез исәп белән тәмамлый алырлар иде.* Р.Нәҗметдинов

**ТУКТАШ** *и. бор.* 1) Яңадан-яңа һөҗүмнәр өчен дошманга якын урында салынган терәк пункт, плацдарм, база. *Тукташка кайту*

2) Каядыр күчеп баручы төркем, халык, күчнең туктап куна торган, ял итә торган мәйданы; стан

**ТУ́К-ТУК** *иярт.* **1.** Агач, таш кебек нәрсәләргә кат-кат бәргәндә чыккан кыска, өзек-өзек саңгырау тавышны белдерә. *Тукран агачларны үлемнән саклый! Тук-тук. Тормыш, яшәү авазы!* Ш.Галиев. *Чүкеч бертуктаусыз «тук-тук» диде, ә өтерге «сук, сук» диде.* Ф.Яруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Аннан тук-тук чапкан балта тавышы дулкын-дулкын булып урман түренә йөгерә-йөгерә дә кинәт тына – каен ыңгырашып ава.* Ә.Еники. *Әгәр җәйге аяк киеме белән тук-тук басып, коридор буйлап атласа, кызлар, аның килүен ишетеп, сүзләрен туктаткан булыр иде.* З.Мурсиев

**ТУК-ТУ́К ИТҮ** *ф.* Агач, таш кебек нәрсәләргә бәрелеп, өзек-өзек саңгырау тавыш чыгару, тукылдау. *Трактор кинәт яман тавыш белән тук-тук-тук итеп ала, акрын гына кузгала.* Ә.Еники. *Бер кулым белән бишеген тирбәтәм, икенче кулым белән --- юеш имезлеген --- авызына каптырам, ---аякларым белән тук-тук иткән тавышлар чыгарам.* Ф.Яруллин

**ТУКТЫ** *и. диал.* Тууына айдан арткан сарык бәтие

**ТУКУ** I *ф.* 1) Аркылы һәм буй җепләрне бик тыгызлап сугып тукыма ясау. *– Мин тукыган паласларны патша йортына илтеп сатсагыз, минем башка эшләремнән алган файдадан йөзләтә артык файда алырсыз, – ди моңа патша малае.* Әкият. *Элгәре замана булса, чүпләм сөлге дә тукып бирер идем үзеңә...* Л.Зөлкарнәй

2) Буй-буй озынча юкә, каеш һ.б.ш. тасмалардан берәр әйбер ясау. *Миңлегали ут яга, Пәтрәй чабата тукый, Шәйхи бабай бүрек ямый.* К.Тинчурин. *Галимулла бабасы аңа чабаталарны вак атламлы, солдатлар кебек тигез рәтле итеп тукый.* А.Хәлим

3) *күч.* Тудыру, барлыкка китерү, иҗат итү. *Сөйли күк Мәрьям апайның, яратып ничек эшен, Тырышып бәхет тукуын Киләчәк көннәр өчен.* Ә.Исхак. *Композитор аларны бер бөтен әсәр итеп тукый.* Җ.Фәйзи

**Тукый башлау** Тукырга тотыну. *Инде Гөлчәһрә оча торган келәмнәр тукый башлагач, зәмзәм суы сатучыларның эшләре хөртиләнгән.* Р.Батулла

**Тукый бирү** Бернәрсәгә карамастан тукуны дәвам итү

**Тукып алу** Бераз туку

**Тукып бетерү** Тукуны тәмамлау. *Бер ай булды дигәндә, бер бик әйбәт палас тукып бетерә.* Әкият. *Мин инде, бер пар чабата тукып бетереп, бирегә җәяү килергә өлгердем.* Т.Гыйззәт

**Тукып карау** Сынау өчен туку; бераз туку. *Чабата тукып караган кеше белә инде безнең эштә күпме акча төшерәсен...* М.Галәү. *Шуннан келәм тукып карарга булдык.* Кызыл таң

**Тукып кую** Тукылган хәлгә китерү, алдан туку

**Тукып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле туку; әле, сөйләү моментында туку

**ТУКУ** II *ф.* 1) Берәр нәрсәгә еш-еш суккалау, шакылдату, бәрү. *[Балалар] өстәл, урындыкларны аударып, аларны йодрыклары белән тукыйлар.* Ф.Бурнаш. *Ике шәһәр арасында поезд чаба. Шүре сыман сәфәр тукып бара: тук-тук-тук!* Ш.Галиев

2) Чуку. *Кортлар, агач кәүсәсенә таралып, урман корткычлары булып китә, кошлар җәмгыяте бу исемсез кошка, агач кәүсәсен томшыгы белән тукып, кортларны чүпләргә куша.* Р.Батулла. *Кәккүк саный, былбыл сайрый – бертын тыңлап бак. Тукран тукый, саесканы – сикертмәләре. Җырлап тора, чырлап тора чикерткәләре.* М.Мирза

3) *күч.* Бер үк нәрсә турында кат-кат әйтү; гел искә төшереп тору. *Чукраклыкның да зыяны юк: барыбер ул кеше сүзен ишетми, үзенекен генә тукый.* Ф.Яруллин. *Бер нәрсәне дә әрәм-*

*шәрәм итмә, сакчыл бул, дип, гел колагыма тукып үстерде.* Ә.Хәсәнов

**Тукый башлау** Тукырга тотыну. *Язуны ташларга, төзелешкә чыгып эшләргә кирәклеген тукый башлаган атасына, Мәҗнүн, акча өчен түгел, күңел өчен язганын --- аңлатып караса да, тегесе барыбер үз сүзендә торды ---.* Х.Ибраһим. *Михаилның кем икәнен белгәч, ул үзенекен тукый башлаячак.* М.Кәбиров

**Тукый бирү** Бернәрсәгә карамыйча тукуны дәвам итү. *Ләкин Гасимә һаман үзенекен тукый бирде ---.* В.Нуруллин. *Тик Рәмзиянең мондый үртәүләргә исе китми, үзенекен тукый бирә.* Ф.Яруллин

**Тукый килү** *к.* **тукып килү**. *Фролов һаман аңа тукый килә: «Замполит, без һәрбер эштә дә икебез бер сүздә булырга тиеш», – дип кенә тора.* Х.Камалов. *Миңа соңыннан әтием-әнием дә, өлкән кешеләр дә: «Һәр ялтыраган алтын түгел», – дип, колагыма тукый килделәр.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тукый тору** *к.* **тукый бирү**. *Артыннан бер адым да калмасам калмадым, мин дә үземнекен тукый тордым.* Ф.Яхин. *Капитан, карчыкны бүлдереп, нидер әйтмәкче булып, урыныннан сикереп торды, ләкин карчык аңа авыз ачарга ирек бирмәде, һаман саен үзенекен тукый торды ---.* И.Диндаров

**Тукып алу** Бераз туку. *Күршеләргә керер алдыннан, Сөмбеләгә нәсыйхәт тукып алдылар: Кызым, Идрис алдында турсаеп утырма, авылдан боегып китмәсен».* К.Кәримов

**Тукып карау** Нәтиҗәне алдан белү өчен туку; бераз туку

**Тукып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле туку. *Баланың тамагын кайгыртма, акылын кайгырт дип, гел тукып килдем бит.* Х.Камалов. *Башта, Караболак радиациядән зарар күрмәгән дип, еллар буе тукып килделәр, инде андый документны тапкач, яңа белешмә сорый башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**Тукып тору** Бертуктаусыз, әледәнәле туку; әле, шушы мизгелдә туку. *Шәкерт абыйлары, әлеге хәрефләр сезгә китапларның могҗизалы серен, көчен ачарга, дөньяны танып белергә ярдәм итәрләр дип, әледән-әле тукып тора.* М.Хәсәнов. *«Барысы да сезнең өчен бит», – дип тукып торырга ярата иде.* Г.Галиева

**Тукып утыру** Шактый озак вакыт туку. *Башкалар ничек кенә сөйли башласалар да, дөрес түгел дип, һаман үзенекен тукып утырды.* Татарстан яшьләре

**ТУКУ** III *ф. диал.* Болгату, туглау, атлау. *Май туку*

**ТУКУВЫЧ** *и. диал. к.* **туглавыч** (*2 мәгъ.*). *Тукувыч белән камыр туглау*

**ТУКУЧЫ** *и.* Туку станында яки махсус станокта тукыма сугучы. --- *Анаңа сөлге-тастымал тукучы иң маһир кызлар күченүчеләр берлән китеп бардылар.* М.Галәү. *Миннән алда сөйләгән нефтьче иптәш ничә мең метр җир бораулавын әйтте, --- тукучыбыз тукымаларның озынлыгын миллионнар белән санады.* Г.Әпсәләмов

**ТУКУЧЫЛЫК** *и.* Туку кәсебе, туку тармагы. «*Кылыч» сүзе торабара тукучылык коралын – туку калагын һәм шул калак функциясен үтәгән --- җайланманы да белдерә башлаган.* Р.Әхмәтьянов. *Казан ханлыгы чорында да тукучылык әһәмиятле урын тоткан.* З.Садыйкова

**ТУКЫЛДАТУ** *ф.* Берәр каты әйбергә тук-тук иттереп еш-еш сугу, бәрү; тук-тук иткән тавыш чыгару. *Староста, авыз эченнән сүгенеп, озын таягы белән аяк астын тукылдатты.* Г.Бәширов. *Һәр көнне өй тирәсендә нидер эшләгән, тукылдаткан, юнган, яңа йорт салырга әзерлек алып барган әтисе, ул кичне барысын да ташлап, Сәлим бай янына китеп барган.* Ф.Бәйрәмова

**Тукылдата башлау** Тукылдатырга тотыну. *Габделхәй, кузгалып китмәкче булып, аягын гына кузгаткан иде, тукран тагын тукылдата башлады.* Н.Фәттах. *Әллә бар мин аңа, әллә юк, озын томшыгы белән тук та тук тукылдата да башлады агачны.* Ф.Шәфигуллин

**Тукылдата тору** Бернәрсәгә карамыйча, тукылдатуны дәвам итү

**Тукылдатып алу** Бераз яки бер тапкыр тукылдату. *Кайдадыр ялгыз тукран гына тук-тук-тук итеп агач тукылдатып ала.* А.Вергазов. *Якында гына бер поши юлны аркылы үтте, --- корыган агачны тукран тукылдатып алды ---.* Ф.Зыятдинов

**Тукылдатып кую** Бер тапкыр яки рәттән берничә тапкыр тукылдату. *– Һай! – дип, таягын тукылдатып куя.* Г.Бәширов. *Аннары кош тәрәзә төбенә очып төште дә томшыгы белән өлгегә берничә тапкыр тукылдатып куйды.* Кызыл таң

**Тукылдатып тору** Әле, шушы мизгелдә тукылдату; бертуктаусыз, әледәнәле тукылдату. *Мәдьяр, сүзенә ышанып җитмәүләренә үпкәләгән сыман, читкә борылып, таягы белән бераз җирне тукылдатып торды.* Г.Бәширов. --- *Миңнулланың бәхетенә, шул тирәдә генә бер тукранның бик кызып тукылдатып торган чагы туры килде.* В.Нуруллин

**ТУКЫЛДАУ** *ф.* Каты нәрсәгә икенче әйбер белән берничә тапкыр сугып тук-тук иткән тавыш чыгару. *Шулай да үҗәт кош эшен ташламады, һаман тук-тук тукылдатуын белде.* К.Тәхау. *Бер колагымда аның тавышы чыңлый, икенчесендә поезд тәгәрмәчләре тукылдый ---.* Р.Габделхакова

**Тукылдап алу** Аз гына тукылдау. *Әти бармаклары белән верстагында тукылдап алды ---.* Г.Бәширов

**Тукылдап кую** Бер тапкыр яки кисәк-кисәк тукылдау. *Минә поезд тәгәрмәчләре рельсларны саный: җай гына тәгәрәп бара-бара да рельс ялгамаларында дәррәү генә тукылдап куя ---.* Т.Нурмөхәммәтов

**Тукылдап тору** Әле, шушы мизгелдә тукылдау; бертуктаусыз, әледән-әле тукылдау

**Тукылдый башлау** Тукылдарга тотыну. *Аннары кайдадыр күзгә күренмәгән тукран тукылдый башлый.* Г.Әпсәләмов. *Турыдан-туры егеткә чүкеч тоттыруы уңайсыз иде, Мәрьям апа, урындыкка басып, үзе тукылдый башлады.* Ф.Яруллин

**ТУКЫЛДЫК** *с. сөйл.* **1.** Тукылдап торган, гел тукылдый торган

**2.** *и. мәгъ.* Тукылдатучы, тук-тук иткән тавыш чыгаручы җан иясе. *Тыраша-тыраша корт чүпләгән тукран янына саескан килеп кунган: «Бу тукылдык чукыган җирдә тәмле-*

*тәмле кортлар мыжлап яталар инде», – --- дип уйлаган.* Ялкын

**ТУКЫЛУ** I *ф.*1) *төш. юн. к.* **туку** I. *Әрмән сатучысы күзнең явын алырлык ачык куе ал, кызыл җепләрдән тукылган бай келәм бүләк итте.* Н.Фәттах. *Ак дөя йонынnan тукылган киезләрдән корылган иркен тирмә эченә узгач, Сәет ишек төбендә үк кинәт торауташтай катып калды.* В.Имамов

2) *күч.* Бер-берсе белән бәйле булу. *Шәхсилек белән гражданлык, бербөтен булып, бер-берсенә тукылып килә.* Н.Нәҗми. *Надиров болай ди: «Өч халыкның фольклорына хас аерым билгеләрнең органик рәвештә үрелеп, тукылып бирелүен күрәбез».* И.Низамов

**Тукылып бетү** Тәмам, барысы да тукылу

**Тукылып кую** Алдан тукылу

**Тукылып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле тукылу

**ТУКЫЛУ** II *ф. төш. юн. к.* **туку** II

**ТУКЫМ** I *и.* 1) Ияр асты киезе, ияр паласы; чапрак. *Мин аның акбүз юргасының ялларын энҗе белән үрер идем, иярене҅ң тукымын укалар белән чигәр идем.* М.Фәйзи. *[Нигә] сөмрәеп утырасың, атыңның ияр, тукымнарын ал да утларга [җибәр]!* М.Гафури

2) Гомумән ат дирбиясе

**ТУКЫМ** II *с.* Туган, кардәш. *Безгә тукым хатын ул*

**ТУКЫМА** *и.* 1) Тукылып ясалган материя. *Шулчакта Равил белән миңа бүләк итеп ялтырап торган атлас тукыма да алып кайтты.* В.Нуруллин. *Әллә кайчан ук юнәтеп куйган чәчәкле тукымадан бәйрәм күлмәге тектерергә өлгермәвемә үкенеп бетә алмадым шул чакта.* Ф.Садриев

2) *биол.* Организмда чыгышлары, төзелешләре, функцияләре белән охшаш булган үзара бәйләнешле күзәнәкләр системасы. *Нерв тукымалары үлә.* Г.Хөсәенов. *Каты агуланганда, берничә сәгатьтән алып берничә тәүлек дәвамына сузылган мускул тукымалары авыртуы яки аяклар параличы күзәтелә.* Агулы үсемлекләр

3) *күч. кит.* Иҗади әсәрнең асылы; иҗади әсәрне тәшкил иткән элементлар, әсәрнең нигезе. *Пьесаның төп материал һәм тукымасында --- кызыклы детальләр [бар].* Н.Исәнбәт. *Романның төп сюжет тукымасы. Әсәрнең тел тукымасы. Балетның музыкаль тукымасы*

**ТУКЫНУ** *ф. кит.* 1) Кул белән кагылу, тию. *Кулларың белән тукына күрмә.* Н.Исәнбәт

2) Намуска, вөҗданга һ.б.ш.га нык тәэсир итү, бәрелү. *Гади бер кычкырып утыру булган бу «җырлаулар» минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар иде.* Г.Тукай. *Тангатаровның исерекбаш белән бәйләнүе Акчулпановның намусына, дәрәҗәсенә тукынды.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Буйсыну, баш ию. *Читен тормыш, капиталга тукынма син.* Г.Тукай

**Тукына башлау** Тукынырга тотыну. *Яралы исә кулын гына селекте һәм, Анна Сергеевнаның беләгеннән тотып, күкрәк турын учы белән ышкыйышкый, тагы: – Миңа куркыныч, коткарыгыз! – дип ялынып тукына башлады.* Х.Камалов

**Тукынып карау** Тукынырга тырышу. *«Син үз балаларыңа үзең дошман, үз балаларыңның хакын эчәсең, ничек оят түгел сиңа?» – дип, Рудный аның намусына тукынып карады.* Х.Камалов

**ТУКЫР** *и. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан ояларын нечкә үсемлек сабакларыннан тукып ясый торган тропик сайрар кош; *русчасы:* **ткачик**

**ТУКЫРДА́У** *ф.* Тыпырдау

**Тукырдап алу** Бер тапкыр яки тиз генә тукырдау. *Тукта әле. Бер тукырдап алыйм әле (Гали такмаклап бии башлый).* Д.Аппакова

**Тукырдап кую** Кинәт тукырдау

**Тукырдап тору** Бертуктаусыз, әледән-әле тукырдау

**Тукырдый башлау** Тукырдарга тотыну

**ТУКЫШ** I *и. иск.* Сугыш. *Туйгужа улы Туктамыш Тукыш белән хан булды ---.* Дастан. *Мин дә эчтем, дуслар. Булды инде тукыш-орышлар.* З.Мәхмүди. --- *Каюм Насыйри Шәгале авылы турындагы язмасында менә нәрсәләр яза: «Тарих тукыз йөз дә илекдә Хаҗ угылы Шиш кяфер тукышында шәһид булды».* И.Тимершин

**ТУКЫШ** II *и. диал.* Пешкән бәрәңгегә он туглап ясалган кош-корт азыгы. *Казларга тукыш кую*

**ТУКЫШУ** *ф. иск.* Сугышу. *Орышып-тукышып, Хаҗи Тарханны алды.* Риваять

**ТУКЫЯ** *и.* Суган кыягының орлыклы башы. *Суганны тукыясы белән өзү*

**ТУКЫЯЛАНУ** *ф.* Суганның тукыясы барлыкка килү. *Быел суган иртә тукыяланды*

**ТУ́К ЭЧӘК** *и. анат. диал.* Юан эчәк

**ТУЛ** *и. иск.* Сугыш аты

**ТУЛА** *и.* **1.** Өйдә сугылган тыгыз, калын, тупас постау. *Кулымны сузып, янымдагы тула төргәгән стена буена ук этәреп куйдым.* Г.Бәширов. *Киез итек, тула баса беләм.* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Шундый постаудан эшләнгән яки тегелгән. *Бу купшы егетләр, --- тула чикмәннәрен ташлап, өстләренә бишбилле җылтыр кара бишмәт киеп, --- кырык тиенлек бәйләм бүрекне маңгайга кырын салганнар.* Г.Ибраһимов. *Ул, чигәсен кашыган булып, тула эшләпәсен маңгаена ук төшереп куйды.* В.Нуруллин

**ТУЛАЕМ** *рәв.* **1.** 1) Бөтенләй, тулысынча; тулы килеш, тулысы белән. *Фәтхулла хәзрәт аңлавынча, дөнья күләмендә танылган астрофизиклар аның фикер сөрешендә һәм хисап нәтиҗәләрендә берниндиkимчелек тә тапмаганнар һәм фаразларын тулаем кабул иткәннәр.* А.Тимергалин. *Әмма язылган өлешен әлегә берәүнең дә тулаем укыганы юк.* Р.Мөхәммәдиев

2) Барысын да, нибарысын, бөтенесен. *[Бабай:] Мин моңа утын саттым. Үгезне, арбаны бирми. --- [Бай:] Тулаем алдым мин.* Әкият

3) Бөтенләе, бөтен барлыгы белән, тулысынча. *Куанганда, тулаем куанырга кирәк. Ярым-йорты хисләр нигә алар!* А.Гыйләҗев. *Ул сагыш шундый татлы, бәлкем, әле генә сине тулаем биләгән тойгылардан татлырактыр да, һәм, ахры, шуңа күрәдер сабый чактагы күз яше кебек ул бик тиз үтеп тә китә...* Ф.Садриев. *Кешелек үзенең бүгенге үсеш дәрәҗәсендә тулаем бер дингә күчәргә әзер түгел.* Р.Сафин

**2.** *с. мәгъ.* Гомуми; тулы. *Габдулла Тукайның күпкырлы --- иҗатына тулаем бер караш ташлаганда, күзне камаштырырлык һәм бер үк вакытта күп кенә каршылыклар да күрәсең ---.* Ф.Хөсни

**3.** *кер. сүз функ.* Йомгаклап әйткәндә, гомуми нәтиҗә чыгарып әйткәндә. *Тулаем, әсәр колхоз сәхнәләрендә куярлык һәм --- сыйнфый дошманга каршы уяулык тудыруда файдалы роль уйнаячак.* М.Җәлил

**ТУЛАЙ** *с.* 1) Гомуми, барлык кешеләр яки барлык нәрсәләр өчен уртак. *Шәкертләр, тулай ашханәгә төшеп, кайнар аш ашыйлар.* К.Тинчурин. *--- Галәветдин агай, --- Казанның икенче төзелеш тресты управляющие белән сөйләшеп, Фәләх белән Розаны шул трестның тулай торагына урнаштырды.* В.Нуруллин

2) *икът.* Чыгым һәм чигерүләрне дә кертеп исәпләнелгән; барлык, бөтен; *русчасы:* **валовой**. *Гомумән, балык продукцияләре крайда җитештерелә торган тулай продукциянең өчтән берен тәшкил итә.* Р.Фәйзуллин. *Аларны гаиләнең тулай кереме яшәү минимумының 130–150 процентыннан артмаган катлам вәкилләренә бирәләр.* Ватаным Татарстан

**ТУЛАК** I *и.* 1) Аяк астына җәелә торган тире. *Ат арык булса, тулак булыр.* Мәкаль

2) Сыер тиресеннән тегелгән күн капчык

3) Чабата яисә итек киер алдыннан аякка чорный торган калын тула яки берәр иске чүпрәк; чолгау

**ТУЛАК** II *и. иск.* «Тай» сүзенә кушылып әйтелә (бишенче яшендәге тай). *Әйе, андый шәп, тай-тулак чаклар да бар иде шул.* Ә.Хәсәнов. *Яшь тай-тулак байтал янында кешнәшә, тешләшә, тибешә.* Р.Батулла

**ТУЛА́ ӨМӘСЕ** *и. этн.* Кызлар җыйналып, кулдан тула басу (гадәттә яшьләр уены белән барган). *Тимеркәй, бездә бүген тула өмәсе була, сине чакырырга килдем.* Т.Гыйззәт. *Менә кайчан кузгала төрле өмәләр: каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе.* Г.Бәширов

**ТУЛА́У** *ф. диал.* Үрү. *Чабата тулау*

**ТУЛАЧЫ** *и.* Тула басу белән шөгыльләнүче; постаучы. *Тулачылар (кызлар) егетләрне тәрәзә аша тула ашы (коймак) белән сыйлыйлар.* Казан утлары

**ТУЛГА** *и. бор.* Сугышта дошман коралыннан саклый торган очлы түбәле металл баш киеме, шлем

**ТУЛГА́Й-ТУЛГАЙ** *рәв. иск.* Әле бер, әле икенче якка сугылгалап, болганып, боргалатып. *Тулгай-тулгай йөгергән, йөгергәндә, җир бавырын кыдырган Тустаган күзле туры атны – аны кая илттең?* Дастан. *Кызның каршындагы киң җилкәле ир, зур гәүдәсен тулгай-тулгай китереп, нигәдер кыбырсына ---.* М.Хуҗин

**ТУЛГАК** *и.* Бала тапканда корсак, аналык мускулларының кискен авыртып кыскаруы-киңәюе; балага авыру. *Истә-оста югында тилмереп бала көткән вакытлары, ике тулгак арасындагы хыялый минутлары күз алдыннан үтте ---.* Г.Галиева. *Туасы сабые өчен ут йотып, ике көн, ике төн тулгак белән җәфаланган хәлсез хатында акча кайгысы була димени?* Р.Габделхакова

**ТУЛГАКЛА́У** *ф.* Балага авыру, тулгак тоту. *Чаршау артындагы ятакта Мәмдүдә килен тулгаклап ята иде.* Р.Батулла. *Тәүлеккә якын тулгаклап, зур газаплар белән, Бибигайшә малай китерде.* Т.Мөбарәков

**Тулгаклап китү** *к.* **тулгаклый башлау**. *Синең кендегеңне дә үзем кистем, килен бакчада бәрәңге чыгарып йөргән җиреннән тулгаклап китте дә.* Г.Якупова

**Тулгаклап тору** Әле, шушы мизгелдә тулгаклау

**Тулгаклый башлау** Тулгакларга тотыну

**ТУЛГА́К ТОТУ** *ф.* 1) Бала тапканда яки бала табар алдыннан, корсак, аналык мускуллары кискен авыртып киңәю-кыскару. *Хәтер сукмаклары Камил белән беренче очраштырган борылышка китереп чыгаргач, Саимәне яңадан тулгак тота башлады.* Г.Галиева. *«Фәнисә әйткән иде аны, кызым бәбәйләгәндә, үземне дә тулгак тотты дип, мине дә тулгак тота бугай», – дип уйлады.* Р.Хәбибуллина

2) *күч.* Нишләргә белмәү; арлы-бирле йөрү. *Сырылма, «тотма тулгак» әйләнәмдә, кит, явыз дошман!* Б.Рәхмәт

**ТУЛГАМАЛЫ** *с. иск.* Борып эшләнгән, борма. *Җавап бирде Норадын: – Тулгамалы айбалтаң Тукыш иткән җырләрдә Уң кулыма алганмын, Алып кайрап салганмын, Карыны юан биләрнең Иңкәйтеп башын алганмын!* Дастан

**ТУЛГАНДЫРУ** *ф.* Гел бер тирәдә әйләндерү; арлы-бирле йөртү. *Археолог, табылма тикшергәндәй, эш коралын әйләндереп, тулгандырып бик озаклап өйрәнә дә төзәтә, ямый, сипли башлый.* Т.Галиуллин. *Су бер әйләндергән, бер тулгандырган үземне, язмышым тулаем язгы ташкын ихтыярында калган.* Р.Мөхәммәдиев

**Тулгандыра башлау** Тулгандырырга тотыну. *Тынгысыз адәм икән. Аркасы, җилкәсе гел уйнап тора, өстәлдәге карандашны кулына алып тәгәрәтә, әйләндерә, тулгандыра башлады.* Т.Галиуллин

**Тулгандырып карау** Тулгандырырга тырышу

**Тулгандырып бетерү** Бик нык тулгандыру. *Дөньяны әллә кайчан әйләндереп, тулгандырып бетерделәр.* М.Галиев. *Соңгы елларны бу тирәдәге авылларны бер кушып, бер аерып тулгандырып бетергәннәр.* Татарстан яшьләре

**Тулгандырып тору** Әле, шушы мизгелдә тулгандыру; бертуктаусыз, әледән-әле тулгандыру. *Чишмә талгын ут өстендә кайнап утыра сыман: төбендә нидер җанланып-җанланып ала, карасуланган яфрак кисәкләрен, ком бөртекләрен айкалдырып, тулгандырып тора.* Л.Зөлкарнәй

**ТУЛГАНУ** *ф.* 1) Гел бер тирәдә әйләнү; арлы-бирле йөрү. *Һади әйләнә, тулгана, мендәрен изеп бетерә, тик йокы һаман килми.* А.Гыйләҗев. *Алан уртасында бары каушавыннан җилкәсенә капчыгын сала алмый аптыраган бер карчык кына, елый-елый, әйберләре тирәсендә тулгана иде.* А.Расих

2) *күч.* Чуалу, буталу, болгану. *Билгеле, Камилне әйтәм әле, дөнья болгана, дөнья тулгана, дөнья иләнә башлау белән, кылчыклы башак кебек калкып килеп чыга ул үзе...* М.Хәсәнов

3) *күч.* Күңелдә, фикердә һаман бер үк нәрсәгә кайту, искә төшерү. *Ә зиһене эшләгәндә берни кыла алмый, уе гел бер тирәдә тулгана: дөрләп янучы йортлары, ачыргаланып кычкыра-кычкыра, ары-бире чабышкан халык һәм ул үзе.* Ф.Хуҗин

**Тулгана башлау** Тулганырга тотыну. *Аннары үтә диндарлык – наданлык билгесе дә ул, ягъни матди дөньядан аерылып, нindидер күзгә күренмәгән җисми дөньяда тулгана башлау.* М.Хәбибуллин. *Күктәге болытларның әвәрә килеп тулгана башлавын да Сәвия әйбәткә юрый алмады.* Г.Гыйльманов

**Тулганып бетү** Тәмам, бик нык тулгану. *Ир балалар булса, кырмыска сыман кыбырсып, кырыкка борылып-тулганып бетәр иде...* Замана сулышы

**Тулганып йөрү** Шактый вакыт тулгану. *Урамнарда тулганып йөри торгач, нindидер ишегалдына кереп туктыйлар.* А.Тимергалин. *Чәчәкләр сатыла торган рәтләрдә шактый тулганып йөргәннән соң, каз оясы кадәр кепка кигән кавказлыдан бер дистә алсу канәфер сатып алды.* В.Имамов

**Тулганып тору** Әле, шушы мизгелдә тулгану; бертуктаусыз, әледән-әле тулгану. *Бераз әйләнеп-тулганып торгач, Ямькиләләр подъездына кереп китте.* Казан утлары

**ТУЛГА́У** I *ф.* 1) Әйләндерү, бөтерү, борып йөртү

2) Болгату

3) *иск.* Импровизацияләү, импровизацион әсәр иҗат итү

**Тулгап алу** Тиз генә яисә бер кат тулгау

**Тулгап бетерү** Тәмам тулгау

**Тулгап карау** Булу-булмавын сынау өчен тулгау; бераз тулгау

**Тулгап тору** Әле, шушы мизгелдә тулгау; бертуктаусыз, әледән-әле тулгау

**Тулгый башлау** Тулгарга тотыну. *Кайнап чыгу белән, борчак консервасын изеп, ботка тулгый башлады.* М.Яһүдин

**ТУЛГА́У** II *и. әд.* Импровизацияләп иҗат ителгән тезмә әсәр. *Борынгы чичәннәр --- кобаерлар, тулгауларны үзенә махсус күтәренке һәм китап әйткән сыман [көйләп] укыган[нар].* Н.Исәнбәт

**ТУЛГЫН** *с.* Тулып торган, кабарып торган. *Быелгы яз көннәрендә моның шикелле дә тулгын һәм матур болыт күренгәне юк иде.* Ш.Камал

**ТУЛКУ** *ф. иск.* Дулкынлану. *Тулкып торган дулкыннар*

**ТУЛКЫН** *и. иск.* Дулкын. *Ярый бәхет бар икән әле: күлдә һичбер тулкын юк, ул бик тын ---.* Г.Ибраһимов. *Фикерләр тулкын кебек кайнаштылар, Җан иясе берсе калмый килде сүзгә...* М.Гафури

**ТУЛКЫНЛАНУ** *ф. иск.* Дулкынлану. *Сизәм: хәзер чәчем тулкынлана.* М.Җәлил

**Тулкынланып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле тулкынлану; әле, шушы мизгелдә тулкынлану. *Һәрбер шау-шулы хәлләрне ярата торган Карлыгач-Сылу, --- җилкәсенә төшеп тулкынланып торган зур кара чәчләрен рәтли биреп, җегеттән вакыйганы хикәя кылдырды.* Г.Ибраһимов. *[Сахарада] тулкынланып торган куе үләннәр дә таба алмыйсың.* Х.Кәрим

**ТУЛКЫНЛЫ** *с. иск.* Дулкынлы. *Хәзер яңа үсеп килә торган тулкынлы яшьлек урынына, үсеп чыныккан табигать өстенлек итә.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Гомернең җил-давыллы һәм туктаусыз тулкынлы чагы үтеп, акрын, гел бертөсле һәм тынычлык сөяр дәвере кереп килә.* Г.Ибраһимов

**ТУЛКЫТУ** *ф. иск.* Дулкынландыру. *Су төбендә асылташ, су тулкытсаң чыгадыр.* Табышмак

**ТУЛМА** *и. кулин.* Тапалган яки тартылган ит белән ярма катнашмасын кәбестә я йөзем куагы яфрагына төреп, я татлы борыч эченә тутырып әзерләнгән ашамлык. *Тулма ясау өчен, бик тыгыз булмаган башлы кәбестә алалар.* Минем йорт

**ТУ́ЛМАУЧЫЛЫК** *и.* Тикшерү вакытында матди җаваплы кеше кулында булырга тиешле акча, мал-мөлкәт җитмәү күренеше. *Ревизия вакытында аның бит бер генә кило да тулмаучылыгы чыкмый торган иде.* Г.Бәширов. *Әтинең нindидер тулмаучылыгын түләттеләр.* Р.Төхфәтуллин

**ТУЛПАР** *и.* 1) Тиз чаба торган, чапкын ат, йөгерек ат. *Аны һаман өч яссылык соклandыра, алгысыта, яшәүгә өнди: ялларын ялкынлатып чапкан тулпар, җилкәннәрен киереп йөзгән кораб, күк гөмбәзен айкап очкан кош.* М.Галиев. *Кисмәй дигән йөзбашы ярсып биеп торган атка, кызыгып, сикереп менеп атланмакчы иде, тулпар кушаяклап тибеп җибәрмәсенме!* Р.Сәгъди

2) *миф.* Әкияттәге канатлы ат. *Борын-борын заманда шушы күлнең төбеннән канатлы ат – тулпар чыккан, ди.* Әкият. *Менә шул атлар арасында берәрсе канатлы тулпар булса, ә?!* Г.Бәширов

**ТУЛТЫРУ** *ф. иск. к.* **тутыру**. *Елтырый күк, елтырый ут чылбыры, Җирне-күкне тултыра чылбыр нуры.* Ш.Бабич

**ТУЛТЫРУК** *рәв. иск. к.* **тулык**. *Сәйфулла шикелле баш-аягы бер казанга тулмас егетләр тагын да тултырук калыр әле.* Ф.Бурнаш

**ТУЛУ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса эчендә буш урын калмау, икенче бер әйбер белән бөтенләй тулы булу. *Түгелергә торган мөлдерәмә чиләккә бер тамчы су җитә: чиләк тулды, тулышты һәм ага башлады ---.* А.Гыйләҗев. *Инде автобуска да утырырга вакыттыр дип ишек янына килсә, аптырап китте: автобус шыплап тулган, аяк басар урын да юк!* М.Вәлиев

2) Берәр нәрсә эченә ни дә булса бик күп керү. *Ул арада көчәйгәннән-көчәя барган дулкыннар, ак тешләрен ыржайтып, яртылаш су тулган көймәне йомычка урынына биетепме-биетә ---.* М.Хәсәнов. *Нургалинең исә чәч араларына, колак тишекләренә ком тулган ---.* М.Мәһдиев

3) Бинага яки башка чикле пространство эченә күп булып, тыгызлап керү, күп булып җыелу. *Тоткыннар --- шуннан соң гына әкренләп бәдрәфкә, юыну бүлмәсенә таба юнәләләр, ә анда кеше тулган, чират.* Г.Әпсәләмов. *Бакчага тавыклар кереп тулган икән.* З.Кадыйрова

4) Берәр урынны биләп алу, җәелү, таралу. *Бакча тәмле алма исе белән тулган.* И.Гази. *Балта эләрлек төтен тулган кабинетка мин кергәндә, төнге сәгать ике иде.* М.Мәһдиев

5) Өлгерү, туенып җитлегү. *Аның беренче җимешләре – чияләр каракуч-*

*кылланып, кура җиләкләре тулып, кызарып килә инде.* Ә.Еники. *Кырларда башаклары тулган арышлар тибрәлә.* А.Нургатина

6) Билгеләнгән мөддәт, вакыт бетү, чыгу, тәмамлану. *[Әхмәт] армиядән соң комсомол путёвкасы белән зур төзелешкә киткән иде. Вакыты тулгач авылга кайткан.* А.Тимергалин. *Гайшәнең төрмә срогы туларга әле шактый вакыт бар иде.* Ф.Бәйрәмова

7) Теге яки бу күләмгә, микъдарга, санга җитү. *Санап унбишәр кешелек төркемгә аергач кына, хикмәт: сан тулмый, җитми бер бала!* Ә.Баян. *Сезгә быел илле яшь тула, диләр.* М.Галиев

8) Билгеле вакыт, ара узу. *Ә бит аларның өйләнешүенә быел җиде ел тулган иде инде.* В.Нуруллин. *Иреккнең Фәнирәләр бүлмәсендә кунып калуына бер ай тулганда, кыз аңа үзенең авырлы икәнен әйтте.* Р.Кәрами

9) Йөкләнгән, билгеләнгән эш, план һ.б. тулысынча үтәлү. *Без, план тулсынтулсын дип, салкында, буранда, яңгырда көн дими, төн дими, --- йөкләмәләрне үтәп йөргәндә, кайберәүләр җылы өйдә хатыннары белән чәй эчеп утырдылар ---.* Г.Афзал. *Син, иялэнү өчен, мәҗбүри рәвештә көненә ун мәртәбә, «әнкәй» дип, әнигә дәшәргә тиешсең. Мин санап барырмын. Көндәлек норма тулмаганда, бабайларга баруны кичектереп торырга кирәк булыр.* М.Мәһдиев

10) Бөтен хәлгә килү, түгәрәкләнү (ай һ.б.ш. тур.). *Шәт, иншалла, юлларың уңар, якыннарың белән кавышырсың, бәдер көн, ягъни ай тулган көнне сәфәр чыгасың.* М.Хәсәнов. *Ләйсән --- өй эшләрен әллә кай арада эшләп бетерә дә: Әйдә бераз йөреп керик әле, әнә бит нинди күңелле, ай тулган чак!» – дип, Рәүфнең теңкәсенә тия иде.* М.Маликова

11) Кирәк кадәрле булу, төгәлләнү. *Шигырьнең юлы тулу*

12) Мәшгуль булу. *Синең көнең ни берлән тулган, беләмсең?* Г.Тукай. *[Аның] һәр сәгате, һәр минуты эш белән тулган.* А.Шамов

13) *сөйл.* Тазару, калынаю; ит куну. *Исламбикә карчык сөякчел бармаклары белән аны капшаштырды: түгәрәкләнеп тулып килгән кулбашларын, эч тирәләрен баскалап карады.* М.Хәсәнов. *Һаҗәр тагын да матурлана төште, күкрәкләре дә тула башлады.* И.Әхмәт

14) Кабару, күперү. *Сөргән җиренең Тулганын күргәч, Җирне яхшылап Түтәлгә өеп, Чәчтеләр орлык Кечкенә дуслар!* М.Җәлил. *Унҗиденең ни икәнен утыз җидедә беләсең. Тулып торган алсу бит алмалары, очынып-кагынып йөргән дәрт икән ул яшьлек!* Ш.Галиев

15) *күч.* Берәр нәрсәнең өсте, йөзе, төрле-төрле яки бериш әйберләр һ.б. белән каплану. *Ни өчен аның түмтүгәрәк йөзе эреле-ваклы каралҗым сипкелләр белән тулган?* А.Тимергалин. *Тышта җылы, күк йөзе йолдызлар белән тулган.* Г.Гайнетдинова // Томалану, каплану. *Гарьлектән, Вакыйфның теле томлыга башлый, күзенә яшь тула.* Р.Мөхәммәдиев

16) *күч.* Берәр төрле хис, теләк һ.б.ш. белән сугарылу, өртелү, тулысынча биләнеп алу. *Ул яшь бәдәненең һәр күзәнәге куаныч һәм гайрәт белән тулганын тоя һәм таулар актарырга атлыгып тора иде.* А.Тимергалин. *Сагыш белән тулды күңелем.* Г.Гайнетдинова

17) *күч.* Тулысынча формалашу, җитлегү (кеше тур.). *Сәгыйдә ул вакытта бик тазарды, нурланды, кыз булып тулды.* Ш.Камал

◊ **Тулган аем** «Матурым», «чибәрем» мәгънәсендә яратып, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Күз нурым син, матурым син, тулган аем! Ай туганда йокла инде, матуркаем!* М.Җәлил. *Син сайрамасаң да беләмен, Айналаем, тулган аем. Чит илләргә озаталар...* Э.Касыймов. **Тулып ашкан** Чиктән тыш күп, артыгы белән. *Ишегалдына чыгу белән, Зариф, бакча башындагы мунчага таба серле генә ым кагып, эче тулып ашкан куанычын карчыгына сиздерәсе итте.* Г.Галиева. *Аның да күкрәгендә чын адәми хисләр тулып ашкан иде, күрәсең.* А.Тимергалин. **Тулып ташкан** *к.* **тулып ашкан**. *Әйтерсең лә табигатьнең тулып ташкан гүзәллеге --- миңа күчкән иде.* Д.Гайнетдинова. *Димәк, бу кызыйның да хисләре тәмам тулып ташкан, кемгә бушатырга белми аптырап, йөдәп йөргән чагы.* Р.Габделхакова. **Тулып яту** Берәр нәрсә еш очрау, бик күп булу. *Җирдә чыннан да яман эшләр тулып ята.* Н.Фәттах. *Тыштан караганда барысы да көйле кебек тоелса да, эчке якта әле өзек-төтекләр, кытыршы яклар тулып ята.* С.Поварисов

**Тула бару** Торган саен, эзлекле рәвештә акрын гына тулу. *Күпме вакыт утыргандыр ул бу сәер хәлдә, әмма ярсуы басыла барган саен, аның бөтен эченә әллә нинди авыр, караңгы бушлык акрын гына тула бара иде.* Ә.Еники. *Иске яфрак һәм урман тузаны, ком һәм балчык җиңнәремә, чалбар балакларыма, авыз һәм борын, колак тишекләренә тула барды.* Ф.Яхин

**Тула башлау** Тулырга тотыну. *Кабинетка врачлар тула башлады.* Г.Әпсәләмов. *Узган гасырның туксанынчы елларында әдәбият-сәнгать өлкәсенә, фән галәменә, шыбырдап, әрсез алабайлар тула башлады.* М.Галиев

**Тула тору** *к.* **тула бару**. *Су тамган турыга ләгән куйган идек, аңа су тула торды, ул тәрәзәгә хәтле күтәрелде.* Г.Әпсәләмов. *Табак өстәлә барды, савытлар, бер-бер артлы йөреп, бушый, яңадан тула торды.* Г.Гыйльманов

**Тулып бару** Тулуга якынлашу. *Инде менә ул дәфтәр дә тулып бара.* Р.Мостафин. *Нәкъ менә шушы чакны аңа ундүрт яшь тулып бара.* К.Җәмит

**Тулып бетү** Тәмам тулу. *Ул --- килеп кергәндә, бөтен театр бинасы, галереясына чаклы, татар җәмгате белән шыгрым тулып беткән иде инде.* Г.Ибраһимов. *Иптәшләре, ашап, йөгереп туйгач, «түрр-түрр» дип, әниләренең канаты астына тулып бетәләр, теге читтә кала.* Ф.Садриев

**Тулып җитү** Тиешле дәрәҗәгә җитеп тулу. *Аның хәзерге тормышы да начар түгел шикелле. Ләкин аңа нидер җитми, ул чишмә суы белән тулып җитмәгән чиләк сымаграк.* Р.Кәрами. *– Менә бүген ай тулып җитте, – диде әти.* Ф.Садриев

**Тулып килү** Тулу алдында булу. *Ә вакыт... вакыт үтә дә үтә, ике атнадан кайтырга тиеш иде, хәзер инде ай тулып килә.* Ә.Еники. *Ә вакыт бик соң: төнгә унбер тулып килә.* В.Нуруллин

**Тулып тору** Тулган хәлдә булу; буш урын калмау. – *Син дә түгәрәкләнеп киләсең, тиздән безгә нәни кашкаңны бүләк итәрсең, – дип, атның тулып торган корсагын сыйпады.* Г.Галиева. *Ул көннәрдә шушы хактагы хәбәрләр Уфа, Оренбург һәм Казан гәҗитләрендә тулып торды.* Р.Мөхәммәдиев

**ТУЛУК** *с.* **1.** Туп-тулы, бөтенләй тулы. *Җамалетдин дусым, --- шундук идән астына төшеп, табак белән тулук бал алып чыга.* Г.Бәширов. *Шул ук музейда узган конференциядә шактый зур зал тулук булган иде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тутырып, туп-тулы итеп. *Онмы, орлыкмы алып бар. --- Олы табакка тулук сал.* Я.Емельянов

**ТУЛЫ** *с.* **1.** 1) Эченә берәр нәрсә салынган, тутырылган; берәр нәрсә бөтенләй тулган, эчендә буш урын булмаган. *Тулы сулы чиләкне алды да, нечкә биле белән бер якка янтая төшеп, кызу-кызу китеп тә барды.* М.Хәсәнов

2) Өстенә, өслегенә берәр нәрсә күпләп куелган, тезелгән; өслегендә нидер күпләп булган; каплап алынган. *Менә алар Ахиярның кабинетына килеп керделәр: өстәл өсте тулы кәгазь, ниндидер схемалар, графиклар, тагын әллә ниләр...* Г.Галиева. *Су өсте тулы ап-ак балык иде.* М.Мәһдиев

3) Күп, мул сулы, суы яр кырыйларына җитеп торган. *Ярсып аккан тулы елгаларда Чыршы, нарат, кедр саллары.* Ш.Мөдәррис. *Бераздан алар тулы сулы киң елганың каракучкыл дулкыннары арасында чайкалалар иде.* М.Хәсәнов

4) Эченә, тирәсенә күпләп кемдер җыелган. *Урам тулы халык: яше, карты-карчыгы, кызы-егете, французы-негры – барысы да джинсыга төренгәннәр.* М.Мәһдиев

5) Таза, көр, симез; тук. *Салмак кына адымнар белән килүче берсен Ләйсирә Закировка охшатты. Тулы гәүдә, озын буй...* Р.Кәрами

6) Күперенке, кабарынкы, туенган (гадәттә, үсемлекләр тур.). *Агач ботаклары ап-ак мамык белән уралганнар да калын, йомшак, тулы булып утыралар.* Г.Ибраһимов

7) Бер состав өлеше дә төшереп калдырылмаган, барысын да эченә алган; барлык. *1918 елны шәһәрдә туган балаларның тулы исемлеге сакланган булып чыкты.* Р.Мостафин. *Мин шәһәр китапханәсендә Герценның утыз томлыгыннан (әсәрләренең тулы җыелмасы) күпме эзләсәм дә, әлеге сүзләрен таба алмадым ---.* А.Тимергалин

8) Гомуми, бөтен, һәрьяклы. *Ниһаять, көтә торгач, Ленинград блокададан азат ителде, ахырда сугыш та бетте, һәм Тамара Сергеевнаның тормышына тулы ачыклык та керде.* Ә.Еники. *Туфан яшәгән һәм иҗат иткән дәвернең тулы картинасын китерергә тырышабыз.* Р.Ханнанов

9) Мөмкин булган кадәр, киң, барлык. *Тоткыннарның хәллерәкләре --- тулы ходка ыргылып барган машинадан асфальт юлга ташланалар.* Г.Гобәй. *Ислам тәгълиматы вә шәригате әлеге мәсьәләдә иң камил гыйлем бирә, --- инсанга шәхси асылына төшенү кирәк булган тулы шартлар тудыра.* Р.Сафин

10) Тулысынча, бөтенләе белән. *Мин Мөбинәгә тулы хаклы яр.* М.Җәлил. *Хәбәр белән җайдак килеп җитә: – Тулы җиңү!* З.Зәйнуллин. *Бер-береңә тулы ышаныч булмаганда, яшәве кыендыр ---.* Т.Галиуллин

11) Кирәкле күләмдәге, нормага тәңгәл булган, төгәл. *Күпмедер вакыт тулы хезмәт хакы алмыйча эшләгән артистлар акчасыз калалар.* М.Маликова. *Шунсыз галимнәребез киләсе елда тулы көчкә фәнни эшләр башкара алмаячак.* Р.Вәлиев

12) Ахырга кадәр җиткерелгән, төгәлләнгән. --- *Мәскәү дәүләт университетының әдәбият факультетында укыдым һәм аның тулы курсын тәнкыйть циклы буенча тәмамладым.* М.Җәлил. *60 ел эчендә Юпитер биш тулы әйләнеш ясый.* Фән һәм тел

13) Бөтен хәлгә килгән, түгәрәкләнгән. *Тулы яшькелт ай арттан безне озата килде.* М.Мәһдиев

14) *мат.* Билгеле бер санның квадратына тигез булган. *4, 9, 16, 25, 36, 49 һ.б. – тулы квадрат саннар*

15) *мат.* Почмакны барлыкка китергән нурлар бер-берсеннән аерылмаган, берсе өстенә берсе туры килгән, 360° ка тигез булган. *Тулы почмак*

16) *күч.* Берәр төрле эш, хис һ.б.ш. белән сугарылган, биләп алынган. *Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән, ашыгып, һаман алга таба тәгәрәде.* Ә.Еники. *Үзенә унсигез яшь, күңеле шатлык белән тулы, хәтере бәхет чүлмәге иде.* Ф.Яхин

17) *күч.* Берәр төрле хисне, кичерешне бик ачык, көчле белдерә торган. *Газзәбануның нәфрәт тулы күзләре көндәшенә текәлде.* Г.Галиева. *Шул ягымлы ирнең үземә текәлгән мәхәббәт тулы назлы карашы гына ап-ачык булып исемдә калды.* Р.Габделхакова

18) *күч.* Вакыйгаларга, эш-гамәлләргә бай. *Тын да алмый тыңладылар: Гайникамал апа укыган, тирән мәгънә, берсеннән-берсе тетрәндергеч вакыйгалар белән тулы дастан торган саен тыңлаучыларны үз эченә «йотты».* М.Хәсәнов. *Отпуск дигәне тиз үтте, ләкин авыр вакыйгалар белән тулы булды.* Х.Мөдәррисова

19) *күч.* Тирән, бай эчтәлекле, хискә бай. *Н.Җиһанов «Качкын»да бик җанлы, тулы эчтәлекле музыкаль образлар тудырган.* М.Җәлил. *Ансыз кызның тормышы тулы түгел, күңеле һаман нидер эзли, аны юксына ---.* Р.Кәрами

20) *күч.* Кирәкле сыйфатларның һәммәсенә ия булган, һәр яктан килгән. *Педагогия, кара карлыган, доклад, балалар, ярыш, комсомол... Тулы кеше син, тормышның тәмен белеп яшисең!* Г.Бәширов

21) *күч.* Бернәрсә белән дә чикләнмәгән. --- *алар Зөфәргә үзе теләгәнчә карап йөрергә тулы ирек биргәннәр иде.* Ә.Еники. *Әнвәрә үзен бу гаиләнең тулы хокуклы кешесе итеп санады ---.* Ф.Садриев

22) *күч.* Атасы да, анасы да булмаган. *Күпчелек җинаятьчеләр тулы ятимнәрдән чыга.* Р.Вәлиев. *Моңа кадәр ярты ятим яшәгән малайның хәзер тулы ятим калуына чын күңелдән әрнеде Илгиз.* Ә.Моталлапов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Һәрьяклап, тулысынча, бөтен сыйфатларын чагылдырып. *Рәхимнең бу юлларында «Хисаметдин менла»ның төп үзенчәлеге, татар әдәбиятындагы роле шактый тулы ачылган.* Х.Миңнегулов. *Бүгенге көндә «бер*

*составлы җыйнак җөмләләр» термины астында йөртелә торган әлеге төр җөмләләр Җ.Вәлиди тарафыннан шактый тулы яктыртылган.* М.Вәлиева

2) Мөмкин булганча, киң, тирән рәвештә; җитәрлек итеп. *Китап турында фикерләреңне тулы итеп язуың өчен, янә дә рәхмәтемне кабул ит.* Ф.Яруллин. *Җиңел генә сорауга да тулы итеп җавап бирә алмыйсың, ә үзең авыр мәсьәләләрне дә ансат кына чишәсең.* М.Хуҗин

3) Җитәрлек итеп, тулысынча; таләп ителгәнчә, тиешенчә. *Язу хакын тулы итеп түләрбез.* З.Бәшири. *Тавыш фазаларының бик азга гына кучүе аркасында җыр күп тавышлы, тулырак булып ишетелә.* М.Мәһдиев

◊ **Тулы түгел** Акылга зәгыйфь, зиһене сай, чамалы; ни акыллы, ни юләр. *Авыл халкыннан кемдер сөйләгән, имеш: – Бу безнең авылга килгән укытучылардан берсе дә тулы түгел. Җыен җен саташтырган кеше безнең мәктәптә, – дигән.* М.Мәһдиев. **Тулы булмаган** *к.* **тулы түгел**

**ТУЛЫ́ВӘКАЛӘТЛЕ** *с.* Берәр юридик документ (мандат, ышанычнамә һ.б.ш.) нигезендә үзенең вазифасында берни белән дә чикләнмәгән хокукка ия булган. *25 июльдә Мәскәүдәге Татарстан Вәкиллегендә энциклопедия редакциясе җитәкчелеге ТРның РФдагы тулы вәкаләтле вәкиле Назыйф Мириханoвка шул медальне тапшырды.* Татарстан яшьләре

**ТУЛЫ́КАНЛЫ** *с.* 1) Бик таза, бик симез, көр. *[Аның] болай да тулыканлы йөзе бурлат сыман кып-кызыл булды.* Ә.Фәйзи

2) *хәрби* Кеше көче һәм техника белән тулысынча тәэмин ителгән, сугышка сәләтле. *Аның урынына резервтан тулыканлы 306 нчы пехота дивизиясе китерелгән.* Г.Сафиуллин

3) Төрле вакыйгаларга, хисләргә бай, җанлы (тормыш, хисләр тур.). *Иҗатым бәрабәренә мин тулыканлы тормышкөнкүрештән баш тарттым.* З.Хәким. *Абыйның чая тәвәккәллегеннән килгән осталыгы нәтиҗәсендә, мин галиҗәнап эшче сыйныфының тулыканлы бер вәкиле булып киттем.* Т.Галиуллин

4) Бөтен таләпләргә җавап бирә торган, һәр яктан камил булмаган. *Драматургия һәм театр (режиссура) сокланырлык эшләнгән, тулыканлы уңай образ тудыра алганнары юк әле.* М.Җәлил. *Язгач-язгач, тулыканлы мәкалә булсын инде ул.* Н.Нәҗми

**ТУЛЫКСА́У** *ф. сир.* 1) Тулы булу, тулып мөлдерәп тору. *Туксанның бере туса, Тулыксаган Идел катар.* Мәкаль

2) Дулкынлану, тибрәнү, комлану (су, елга тур.). *Әнә, күрәсеңме, елгабыз тулыксый.* М.Галиев

**Тулыксап тору** Сөйләү моментында яисә даими тулыксау. *Күл бик зур, суы тулыксап тора.* Казан утлары

**Тулыксый башлау** Тулыксау билгеләре күренү

**ТУЛЫКСУ** *ф. сир. к.* **тулыксау**. *Тулыксыган Иделне Туңмас борын кичиек! Үләр булган Идегәй Үлмәс борын алыек!* Дастан

**ТУЛЫКСЫЗ** *с. диал.* Тулы булмаган; тулып җитмәгән. *Тулыксыз савыт*

**ТУЛЫ́КЫЙММӘТЛЕ** *с.* 1) Билгеле, кабул ителгән бәягә, кыйммәткә ия булган; бәясе төшмәгән, кыйммәтен югалтмаган (акча, валюта тур.)

2) *куч.* Куелган таләпләргә тулысынча җавап бирә торган. *Ата-аналар, үз чиратында, баланың җылы киенүен, судан чыккач өшемәвен, тулыкыйммәтле туклануын күзәтергә тиеш, чөнки судагы күнегүләр күп көч ала.* Ютазы таңнары

**ТУЛЫЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Элек булганга өстәү; җитмәгәнне өстәү; тулы иттерү. *Аның төп фигурасын күреп алгач, тулыландыру артык кыен түгел, ул инде хыял эше, хыял бай булса, аныңсы ансат.* Г.Бәширов. *Бу хезмәт аерым китап рәвешендә чыкса да, алга таба мин аны тулыландырырга телим.* Р.Фәйзуллин

2) Тиешле санга, комплектка җиткерү. *Камал исемендәге театр труппасын яшь артистлар белән тулыландыру фикерен Татарстан Мәдәният министрлыгына ул җиткерә.* Т.Миңнуллин. *Аннары армия сафларын тулыландырып, Германиядә өч ел хезмәт иттем.* М.Нурулла

**Тулыландыра бару** Торган саен тагын да ныграк тулыландыру. *Ул музейны яңа экспонатлар белән тулыландыра бара.* Ф.Гарипова. *Г.Ибраһимов әсәрнең буеннан-буена авыл тасвирын тулыландыра бара, әмма кабат аның күренешләренә әсәр башындагы кадәр тукталмый инде.* Р.Рахман

**Тулыландыра башлау** Тулыландырырга тотыну. *Өстәвенә бу елларда югалту бушлыгын тиз арада яңа көчләр тулыландыра башлый: --- Шамил Сабиров, Нәсимә Җиһаншина, Җиһангир Җиһаншин, Әхмәдиша Җиһаншин, Пётр Улыбашев кебек киләчәктә театрның данын куәтләүче театр әһелләре килеп кушыла.* Д.Гыймранова

**Тулыландыра килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә, даими тулыландыру. *Исхакыйның берсе икенчесен тулыландыра килгән мәкаләләрендә «эшкә җигелгән» барча әдәби, публицистик чаралар татар шигъриятенең алтын баганасы Тукай образын якты, күркәм шәхес итеп сурәтләү максатына багышланганнар.* Т.Галиуллин

**Тулыландыра тору** Әледән-әле тулыландыру. *Кыскасы, мәктәпнең туган якны өйрәнү музее яшьләрне халкыбызның данлы традицияләрендә, өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләүгә зур өлеш кертә, ә укучылар музейның эчтәлеген баета торган кыйммәтле һәм кадерле экспонатлар белән аны тагын да тулыландыра тора.* Мәдәни җомга

**Тулыландыра төшү** Бераз тулыландыру; тагын да тулыландыру. *Галиев һәм башка чыгыш ясаучылар Уфадан килгән олуг шагыйрь образын тагын да тулыландыра төшteләр.* Н.Нәҗми

**Тулыландырып бару** Эзлекле рәвештә тулыландыру. *Әдип үзенең әйткән фикерләрен кайчакны кул хәрәкәтләре белән дә нигезләп, тулыландырып бара иде.* Р.Низамиев

**Тулыландырып җибәрү** Булганга өстәү; тагын да ныграк тулыландыру; тулы итү. *Шул егетнең дусларча кочаклап күрешүе, өстәвенә мактау сүзе әйтеп куюы шатлыгымны тулыландырып җибәрде.* М.Әмир. *Бу хезмәт аның тормышын тагын да тулыландырып җибәрә.* Т.Нәҗмиев

**Тулыландырып тору** Даими тулыландыру. *Ә аны шул ук фотоэлементлар*

*тулыландырып тора.* И.Хуҗин. *Тарих, тарихи вакыйгалар, тарихи бөек шәхесләр һәркемнең эчке дөньясын баетып, тулыландырып торырга тиешләр.* Р.Батулла

**Тулыландырып чыгу** Берәм-берәм барысын да тулыландыру. *Мәктәп китапханәләрен тулыландырып чыгарга кирәк хәзер.* Ялкын

**ТУЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Тулы (*1–2 мәгъ.*) хәлгә килү; арту. *Ике атна узуга, операция өстәле барлык инструментлар белән тулыланды.* Ф.Яруллин. *Парк ел саен үзебезнең һәм чит ил техникасы белән тулылана.* Кызыл таң

2) Тазару, түгәрәкләнү, симерү. *Сәламәтлеге әйбәтләнә, гәүдәгә тулылана, дим.* М.Хуҗин. *Фирая балага узмады, әмма тулыланып, тагы да матураеп китте.* Д.Бүләков

3) Туену, тук хәлгә килү, тулу (үсемлекләрнең орлыгы, җимеше тур.). *Арпа һәм солылар озынга күп үсә алмасалар да, башлары ярыйсы гына тулыланды.* Ш.Камал

4) *күч.* Бар яктан да җитеш хәлгә килү; һәр ягы тулы, җитеш булу. *Яшьлек эзләре буенча хыялларга бирелеп бер йөрсә, күңелләре тулыланып, җаны бөтенәеп, мәңге төзәлмәс йөрәк яралары чак кына язылып китәр сыман иде.* М.Хәсәнов

**Тулылана бару** Вакыт үткән саен күбрәк тулылану. *Гамь агачының яфраклары шыбырдашырга тотынган, һәм күзгә күренеп җимешләре зурая, тулылана барган.* Ф.Яруллин

**Тулылана башлау** Тулыланырга тотыну; тулылану билгеләре сизелү. *Өстендә аның инде тулылана башлаган гәүдәсенә ыспай ятып торган тар итәкле ачык изүле әфлисун төсендәге йон күлмәк, аягында кара «лодочка» туфлиләр, ялангач беләгендә кечкенә алтын сәгать.* Ә.Еники

**Тулылана төшү** Тагын да тулылану. *Дөнья матурая төшкән кебек күренә: ничектер тыгызлана, тулылана төшкән кебек.* Х.Туфан. *Дәреслекнең яңа басмасы, минем уемча, тагын да камилләшер, тагын да тулылана төшәр.* Х.Миңнегулов

**Тулыланып җитү** Тәмам тулылану. *Кирәкле әсбаплар тәмам тулыланып җитте дигәндә генә шундый хәбәр килеп ирешә.* Казан утлары

**Тулыланып килү** Әкренләп тулылану. *Газзәбануыбыз да күзгә күренеп тулыланып килә.* Г.Галиева. *Әдәби методлар, юнәлешләр, алымнар гасырлар буена үзгәреп, тулыланып килгән.* М.Кәбиров

**Тулыланып китү** Кисәк, тиз арада тулылану. *Ул тыштан әллә ни үзгәрмәгән, тагы да тулыланып, матураланып киткән иде.* Х.Камалов. *Ул түргә узуга, ниндидер яңа төс белән куерып, бәйрәмнәре тулыланып китте.* Ф.Яхин

**Тулыланып тору** Даими тулылану; тулыланган булып күренү. *Казан аксөякләре составы даими тулыланып торган, алар арасына Нугай урдасыннан, Касыйм, Себер ханлыкларыннан бәк һәм морзалар өстәлеп торган.* Б.Хәмидуллин

**ТУЛЫЛАП** *рәв. к.* **тулысынча**. *Ә хәзрәтнең сөргендәге тормышы турында авылда берәүгә дә тулылап сөйләмәгәнсең.* М.Хуҗин. *Әмма бүген дә, шушы дүрт юллык шигырьнең тууыннан соң дүрт дистә ел узгач та, тирәюнебездәге бер хәлгә, күренешкә, тулылап атасак, агымга текәлеп карыйк әле.* Татар әдипләре

**ТУЛЫЛА́У** *ф.* Тулылык (*2, 6 мәгъ.*) өстәү, тулыландыру. *Матурлыгын холкы тулылый.* Әйтем

**Тулылап тору** Тулылауны дәвам итү

**Тулылый башлау** Тулыларга тотыну. *Папкаларны тикшереп, кирәкле кәгазьләрне тулылый башларга вакыт җитте.* Т.Галиуллин

**Тулылый төшү** Тагын да бераз тулылау. *– Мин элек язганнарымны тулылый төштем әле, карап чыгарсың әле, – диде ул уңайсызланып кына.* И.Нуруллин

**ТУЛЫЛАУЧЫ** *с. мат.* Суммалары туры почмакка (90° ка) тигез булган (мәс., 40° һәм 50° лы) ике почмак тур. *Тулылаучы почмакларны табарга һәм үлчәргә кирәк.* Математика

**ТУЛЫЛЫК** *и.* 1) Берәр нәрсә белән тулы (*1 мәгъ.*) булу хәле, сыйфаты. *Авторның бу китабы да, башка хезмәтләре кебек үк, тулылыгы, нәтиҗәлелеге белән игътибарга лаек.* Э.Кадыйрова. --- *без, карын туклыгы, кесә тулылыгы артыннан чабып, рухи азык савытларына көндәлек кирәк-ярак турабыз: заманны сүгәбез, шыңшыйбыз, үпкәлибез.* Шәһри Казан

2) Тазалык, түгәрәклек. *Йокы, алсулык, тулылык ник качты?* Р.Гаташ. *Яшьлеге, тулылыгы сулганчы, гүзәлкәй белән мактанып калырга кирәк.* Н.Сәйяр

3) Өлгергән вакытта сокны мул җыйган булу (җиләк-җимеш тур.). *Чияләр, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар.* Г.Кутуй. *Җиләкләрегезнең тулылыгы, сусыллыгы ошады безгә, бернигә төп кенә булса да үзебезгә дә утыртыр идем.* Сөембикә

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса барлык сыйфатларының җыелмасы, асылы. *Дирижёр бөтен сәхнәне бар тулылыгы белән күз уңында тота икән.* Ф.Яхин. *Шул сәбәпле аерым чорларны, мәсьәләләрне, әдипләрне тикшерүдә тулылык, объективлык җитми.* Х.Миңнегулов

5) *күч.* Байлык, муллык, җитешлек. *Алар тормышында да бәхет, тулылык сизелми.* Р.Рахман

**ТУЛЫМ** I *и. диал.* Елгада су астыннан чыгып торган ташлар. *Агып барган бүрәнә тулымга бәрелде*

**ТУЛЫМ** II *и. тарт. форм.* «Туптулы, мөлдерәмә» дигәнне аңлата. *[Ул] кечкенә чокырга күз тулымы аракы сала.* Ә.Еники. *Уч тулымы*

**ТУЛЫ́МЕТРАЖЛЫ** *с.* Озынлыгы гадәти бер сеанста күрсәтергә җитәрлек, башка фильмнардан кыска булмаган. *Фәрид Дәүләтшинның тулыметражлы «Эт» фильмы 50 мең сумлык, анысын да режиссёр үз кесәсеннән чыгарган.* Сөембикә

**ТУЛЫМСА** *с.* Тулы, кабарып торган; таза, итләч. *Бүген дә Фарук уйларының очына җитә алмады, аның янына тулымса гәүдәле, зуррак башлы малай һәм җыйнак гәүдәле, җитезҗәһәт хәрәкәтле, томрый кара озын куш толымлы кыз якыная иде.* М.Хуҗин

**ТУЛЫН** *и. монг. бор.* Су салып йөртә торган тире капчык; турсык, саба. *Тулынга су тутыру*

**ТУЛЫНКЫ** *с.* Тулып, мимылдап тора торган; симез. *Күрде ич, җаныттәне белән тойды: ул аңа җиңгәчәсе*

*итеп кенә карамады, ул аңа сокланып карады, яшь кеше бар яктан да тулынкы булган хатын-кызга караган кебек.* М.Хәбибуллин. *Тулынкы иренле бу ханым миңа бер дә ошамады.* Ф.Баттал

**ТУЛЫСЫ́НЧА** *рәв.* 1) Барысын да, бүлгәләмичә; бөтен килеш. *Иргали абыйсы бөтен гайрәтен, сәламәтлеген биреп тапкан мал-мөлкәтен тулысынча колхозга тапшырган.* М.Хәсәнов. *Ял итү зонасына дигән төзелеш материалларын тулысынча яңа посёлок төзелешенә күчерергә!* Р.Вәлиев

2) Бөтенләй, бөтенләе белән; тулысы белән. *Мәҗлес тулысынча җыр карамагында, шуның тәэсирендә иде, керәшен кызын бер җыр белән генә ычкындырмадылар.* М.Мәһдиев. *Маршал Гречко үзенең болай да кечкенә булган авторитетын тулысынча җуйды.* З.Зәйнуллин

3) Ахырына кадәр, җиренә җиткереп, төгәл итеп. *Кайсы гына очрак булмасын, табиб күзәтүе астында тулысынча дәвалану мөһим.* А.Әпсәләмова. *Мәхәббәткә, сөйгәненә булган тугрылыгын тулысынча һәм оста итеп сурәтләүдә Хәсән Туфан ел фасылы язга мөрәҗәгать итә.* З.Шәйхуллина

**ТУЛЫ́ТАВЫШЛЫ** *с.* Һәр төр югарылыктагы, тембрдагы тавышлар чыгарырга сәләтле; киң диапазонлы. *Сезнең кызыгызның тавышы искиткеч, андыйларны «тулытавышлы» диләр, аңа опера җырчысы булырга кирәк.* Йолдыз

**ТУЛЫ́ХОКУКЛЫ** *с.* Барлык хокукларга ия булган. --- *ул үзен коллектив дигән гаиләнең тулыхокуклы әгъзасы итеп тоймый.* Р.Кәрами

**ТУЛЫШУ** *ф.* 1) *к.* **тулу** (*6 – 10 мәгъ.*). *Аларның аксыл яшькелт башаклары комсызланып кояш нурын эчә, башаклар тулыша һәм алтынсу сары төскә керә, агара бара.* Н.Әхмәдиев. *Таифә карчык, аның ни әйтергә теләгәнен ярты сүзеннән аңлап, туры караган кояштан нурга тулышкан Сакмар кебек яктырып китте...* Ф.Сафин

2) Кабару, шешү. *Аның тулышкан иреннәре минем дымлы иреннәремнең түмен тою белән, сөеклемнең һәр әгъзасы күз ачып күз йомганчы гүя тораташка әйләнде.* К.Миңлебаев. *Ана кеше нарасыена сөт белән тулышкан күкрәген каптырды.* Р.Сәгъди

**Тулыша бару** Торган саен ныграк тулышу. *Аннары ул дәрткә тулыша барган тәнендә кызның йомшак кулларын тойды; ул куллар аны сөю-мәхәббәт иленә, бәхетнең җиденче катына чакыралар иде...* Г.Гыйльманов. --- *алга таба да Сөрмәя, Ходай хикмәте, үскән саен тагын да матурлана-чибәрләнә, бүген-кичә генә бакчада пешкән алма кебек тулыша барды.* Ф.Яхин

**Тулыша башлау** Тулышу билгеләре сизелү; тулышырга тотыну. *Тау битләрендә күзгә күренеп җиләкләр өлгерде, шомырт пеште, чикләвекләр тулыша башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Чияләр дә тулыша башлаган, карлыганга да кояш кунган...* Г.Гыйльманов

**Тулыша килү** Күптәннән һәм эзлекле рәвештә тулышу. *Ниятем шагыйрьнең яңа шигъри җыентыкларын укыганда тула-тулыша килде, һәм, ниһаять, аның бу китабын укып чыккач, кулга каләм алдым.* Казан утлары. *Авторда шагыйрьлек, күрәсең, күптәннән түл җыеп, тулыша килгән.* Кызыл таң

**Тулыша төшү** Тагын да бераз тулышу. *Чөнки кияүгә чыкканнан соңгы дүрт ел дәвамында Фәгыйләнең бармаклары шактый тулыша төшкән, тирән батып кергән алтын балдак сары тегәрҗепкә охшашлы сызык кына булып күренеп тора.* С.Сабиров

**Тулышып җитү** Тәмам тулышу. *Болытның да үз хыялы: «Тулышып җитсәм әгәр, Ташлап бушлыкның катларын, Җиргә төшеп килешкә, Кушылыр идем тамчы булып Чишмәгә я инешкә».* Р.Фәйзуллин. *Тулышып җиткән башаклар, комбайн көтеп, башларын түбән игән.* Сөембикә

**Тулышып килү** Әкренләп тулышу. *Тулышып килгән матур, зифа буй-сынлы бер кыз иде ул.* Х.Камалов. --- *бәла эренләгән шеш шикелле акрынлап тулышып килгән, аны күрмәү мөмкин дә булмаган.* З.Мурсиев

**Тулышып китү** Тулышкан хәлгә килү. *Ашыкма, гәүдәләрең бераз тулышып китсен.* Л.Ибрагим-Вәлиди. *Әбүзәр аның саен тәмле телләнде, баш җитмәслек вәгъдәләр бирде, көлде, шаяртты, Бәхетне бүлмә буйлап күтәреп йөртте, аның кызу битеннән, маңгаеннан үпте, аннары, кызның ярсынудан тагын да тулышып киткән күкрәкләренә башын куеп, тынып калды...* Шәһри Казан

**Тулышып тору** Хәзерге вакытта тулышкан хәлдә булу. *Аяклары да тулышып торалар.* Ф.Яхин. *Аның тулышып торган кызгылт бите соңгы көннәрдә бераз сулыга башлады.* К.Кәрами

**ТУМ** *кис.* Кайбер сыйфатлар белән килеп, артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Тум-тулы сандыкка теләсә кем кызыгырлык иде.* К.Нәҗми. *Аның гәүдәсе кеше гәүдәсенә охшаса да, бик үк зифа түгел: толымы җиргә җитеп бик озын, башы, озынча күзләре бик зур, тум кара, атылып чыгып тора, кашлары юк (шуңа күрә, кашы бик сирәк булган кешегә дә су анасы диләр), күкрәге бик киң һәм алга калкып тора, тәне бакыр сыман кызыл була, ди.* Җен-пәриләр бар, диләр...

**ТУМА** *и.* **1**. 1) Нәсел, токым. *Ул сыерның кайдан чыкканлыгын, аның кем тумасы булганлыгын, ничә яшьлек икәнен [сөйли].* М.Гали

2) Карындагы яралгы. *Туманың нормаль үсеше өчен, кәҗәләрне бөтен буазлык чорында, бигрәк тә аның икенче яртысында, яхшы ашатырга кирәк.* Йорт эшләре

3) Теге яки бу урында туып үскән, шуннан чыккан кеше. --- *бу киң күңелле Кәче тумасы кеше өенә кунак чакырырга батыр батырлыкка да, әмма теге ни... без кайтып ишелергә тиешле өйнең хуҗалары булырга тиештер бит әле: алар ничек карар без юлдан табылган кунакларга?* Ф.Хөсни. *Сүз уңаенда бу мөхтәрәм галимнең шушы төбәк тумасы икәнен, балигъ булганчы Бөгелмәдә яшәгәнлеген, шушында укыганлыгын, берара эшләгәнлеген әйтик.* Мәдәни җомга

4) Билгеле бер урында туган хайван турында. *Гүр садакасына зур бер сарык бирдем, фидиясенә, өй тумасы кашка кырыкмыш бар иде, шуны бирдем, кырыгына кадәр өстенә йөрергә алты тәкәдән теккән тунын бирдем.* Г.Исхакый. *Ул инде бездә сыналган ат,*

*күрше авыл тумасы, аны карап та торасы юк.* М.Гали

5) Билгеле бер социаль мохиттә тәрбияләнгән, шуннан чыккан кеше. *[Сәфәргали] бу киеренке казарма шартларында үзенең чынлап та авыл малае, крестьян тумасы икәнлеген сизә башлады.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* 1) Билгеле бер урыннан, җирлектән булган (үсемлекләр, хайваннар һ.б. тур.). *Хәсән исә үзебезнең йорт тума чәчәкләрне урманнарда, кырларда эзләп табып, үз кулы белән алып кайтып утырткан.* Г.Бәширов

2) Бертуган. *Ахмаклык һәм хайванлык – бер тума агай-эне кебек бит алар, һаман да бергә, кулга-кул тотышып йөриләр.* Ф.Яхин. *Әкмәли малае: «Әти, мин атымны алыштырмыйм, кунак җегете алыштырсын». «Ул сиңа кунак җегете түгел, туксан тугыз тапкыр әйттем, синең тума энең».* В.Ильясов

3) Тумыштан килгән. *Әлбәттә, шәкерт Тукайның тума, табигый зирәклеген, талантын иске мәдрәсә шартлары томалап калдырган да булыр иде.* Казан утлары. *Мәсәлән, тома (сукыр, надан), шома сүзләре гап-гади (диалекталь) «тума – тумыштан» һәм «шума – шуу өчен җайлы» сүзләреннән икәнлеге мәгълүм була.* Р.Әхмәтьянов

4) *күч.* Нәрсәнеңдер нәтиҗәсе булган, ни дә булса тудырган, барлыкка китергән. *Октябрь революциясе Россиядә буржуаз төзелешне җимергәч, ул төзелешнең тума балалары да [бетте].* Ф.Әмирхан

**3.** *кис. функ.* Бөтенләй, тәмам. --- *Сабирның «ирек сөючән табигате» аны бөтен тирә карашына каршы килеп, авылга җибәрсә һәм, ахыр килеп, тума надан, ләкин шат, шаян, кеше гаепләренә игътибар итмәүчән ирекле табигатьле бер кызга өйләнеп, ахырдан атасы ташлап киткән «ояны» тергезү эшенә керешүче итсә, Зыя табигате аны бөтенләй башка юллар белән җибәрә ---.* Г.Нигъмәти. *Җансыз агачтан җан, тума сукырдан күз көттек.* Татар фольклоры

**ТУМАК** I *и.* 1) Казак һәм кыргызларның милли баш киеме

2) Ау кошының башына кидерелә торган калфак. *Кошның тумагы күзенә төшкән*

**ТУМАК** II *и. диал.* 1) Уйнаштан туган бала

2) Чәчмичә яки утыртмыйча, үзлегеннән тишелгән иген яки яшелчә. *Тумак басуы*

**ТУМАЛАК** *с.* **1.** *диал.* Түгәрәк. *Туптумалак битле бер малай иде ул.* Мирас

**2.** *и. мәгъ.* Ат тизәге. *Моннан котылдыру өчен, ат тумалагы белән шул тишекне тутырырга, аннан соң өстән имән казык кагып куярга кирәк.* Әкият

**ТУМАЛДЫРУ** *ф. диал.* Турсайту, кабарту. *Авызын тумалдырып карап торган бу балага ни диясең инде?* Казан утлары

**ТУМАЛТУ** *ф. диал.* Турсайту, кабарту. *Авыз тумалту. Ирен тумалту*

**ТУМАЛУ** *ф. диал.* Турсаю, кабару. *Авызга бик зур калҗа капкач, чәйни торган яктан бит тумалып чыга.* Ж.Вәлиди

**ТУМАР** *и. диал.* 1) Бүкән, кискә. *Тумар кадәр йодрыгына, уклау юанлыгындагы кыска бармакларына карап куйды.* Ә.Моталлапов. *Бабай тумар өстенә утырып тәмәке көйрәтә иде.* Сөембикә

2) *бор.* Тупыйк очлы ау угы. *Бер кабиләдән икенчесенә илче булып килгән кеше ят кабилә башлыгының йортына якынлашкач, үз кабиләсе өчен хас булган формадагы берничә тупак ук – тумар ата торган булган.* Р.Әхмәтьянов

**ТУМАРБАШ** *и. бот. диал.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан эфир маена бай куак яки үлән үсемлек; чабыр. *Тумарбаш дәвалау өлкәсендә дә кулланыла.* Файдалы киңәшләр

**ТУМАРЛА́У** *ф. диал.* Кабарту. *Тумарлаган туп кына, аягы-кулы юк кына.* Табышмак

**ТУМА́ ТУДЫКА** *и. диал.* Бертуган апа яки сеңел

**ТУМАЧА** *и.* 1) Кардәш, туган. *Аның шундый берәр тумача булуы әйбәт тә әле.* Р.Зәйдулла. *Көрәшчеләргә бай компанчыларга еракта килгән тумача булуы да бар.* Ватаным Татарстан

2) *к.* **тумачи**. *Тумачам кунакка килде әле, озаклап сөйләшеп утырырга җай да чыкты.* Р.Вәлиева

**ТУМАЧИ** *и.* 1) Туганнан туган кардәш хатын-кызлар бер-беренә яратып, үз итеп эндәшә торган сүз. *И тумачи, әллә кайчан синең белән киңәшәсе калган икән миңа.* Казан утлары

2) Гомумән туганнарга үз итеп, яратып яки олылап эндәшә торган сүз. *Тумачи җиңгиләр, Апак абыстайлар алар – үз кеше.* Г.Камал. *Ул да, «тумачи җиңги, ап-ак абыстай һәм Фатыйма тудыклар»ны сагыз урынына чәйни.* М.Гали. *Моны астан гына Гөлсаф тумачи оештыра.* Х.Камалов

3) *диал.* Өченче буын кардәшләр бер-беренә яратып әйтә торган эндәш сүз. *Бумази күлмәген киеп, чәй ясады тумачи.* И.Гази

**ТУМАЧИ́ ӘНИ** *и. диал.* Әти яки әнинең бертуган апасы. *Тукта, Мәхүп, мин сезгә бер сүз сөйлим, мин яшь вакытта тумачи әни сөйли торган иде ---.* Ф.Халиди

**ТУ́МБА** *и. гр.* 1) Юл яки тротуар кырыена утыртылган тәбәнәк багана. *Сатыла торган урынга җир астына бата торган тумба куялар, аны батырып, өстенә автомобиль кую өчен исә акча түләп, махсус электрон билет сатып алырга кирәк.* З.Мифтахов. *Игъланнар өчен юл кырыена яңа тумбалар утыртып чыктылар.* Мәгърифәт

2) Судноларны причалга бәйләп кую өчен, гөмбә формасындагы тәбәнәк юан тимер, чуен казык. *Басмалар инде алынган, юеш арканнарның элмәкләрен генә чуен тумбалардан ычкындырасы калган иде.* К.Нәҗми. *Аннары йөгерә-атлый барып, борындагы чуен тумбадан сүс арканны ычкындырып җибәрде.* Х.Сарьян

3) Берәр нәрсә астына куела торган бүкән. *Кырыйдагы тумбалар өстендә куыклары яртылаш кырылып, корымланып беткән берничә лампа яна.* Ш.Маннур

4) *сөйл. к.* **тумбочка**. *Тумба өсте җиләк-җимеш, тәм-том белән тулды.* Р.Габделхакова. *Иплән кенә урынынnan торды да телефон куелган тумба янына атлады.* С.Зыялы

**ТУ́МБОЧКА** *и. рус* Гадәттә, карават, эш өстәле һ.б. янына урнаштырыла һәм кирәк-ярак саклау өчен кулланыла

торган тәбәнәк кечкенә шкаф. *Тулай торакта бердәнбер телефон, ул аскы катта, ишек төбендә кизү торучы Наилә апа янындагы тумбочкада тора.* М.Маликова. – *Әйдә... – диде Фатыйма карчык, ишек төбендәге тумбочкада утырган электр плитәсен кушып. – Чәй эчеп алырбыз.* М.Кәбиров

**ТУМПА** *с. диал.* Кабарынкы. *Тумпа битле. Тумпа иренле*

**ТУМПАЙТУ** *ф. диал.* Бүлтәйтү, кабарту. *Иренне тумпайту*

**ТУМПАК** *с.* Җәенке, кабарынкы. *Нәҗип акча кызганмады, Ленин урамындагы антиквариат кибетеннән тумпак борынлы, йомшак иренле негрларның кара агачтан кырып ясалган сыннарын алып кайтып, дача киштәсенә тезде.* А.Гыйләҗев. *Ул арада җир астыннан гына күтәрелгәндәй, башнясына тәре сурәте төшерелгән тумпак борынлы танклары да калкып чыкты.* М.Әмирханов

**ТУМПАКЛАНУ** *ф.* Җәенкеләнү, җәенке хәлгә килү. *Кызган тимер башы тумпаклану*

**Тумпаклана бару** Акрынлап, азазлап тумпаклану. *Тупылларның башы тумпаклана бара*

**Тумпаклана башлау** Тумпаклануга таба бару. *Киез итекнең башлары тумпаклана башлаган*

**Тумпаклана төшү** Тагын да бераз тумпаклану. *Чүкеч башы тумпаклана төшкән*

**ТУМПАКЛЫК** *и.* Тумпак булу; җәенкелек. *Борынының тумпаклыгы үзенә килешеп тора тагын.* Р.Вәлиева

**ТУМПАЮ** *ф. диал.* Бүлтәю, кабарып чыгу (гадәттә, авыз тирәсе тур.). *Сугышмадым дигәнгә кем ышаныр: аскы ирен тумпайган, күз төпләре күгәргән...* Н.Акмал

**Тумпаеп тору** Озак вакыт дәвамында тумпайган хәлдә булу; һәрвакыт тумпаю; сөйләү моментында тумпаю. *Йомры башлы, бераз яльпәгрәк танаулы, калын иреннәре алга тумпаеп торган зур авызлы һәм, башы белән чагыштырган чакта, шулай ук чамадан тыш зур аркылы колаклы бу шәкертнең куллары исә үзләре ябык, үзләре бәләкәй һәм бармаклары нәзек иде.* Әдипләр

**ТУМРА** *кис. диал.* Төсне белдергән сүзләр, башлыча, *кара* сүзе белән килгәндә «үтә, бик» мәгънәсен белдерә. *Тумра кара чәч*

**ТУМРАЙТУ** *ф. диал.* Күзләрне тутырып, мөлдерәтеп туры карау; томырып карау; томрайту. *Күзләрен тумрайтып карап тора бит, ничек чакырмыйсың ди аны.* Г.Кашшаф

**ТУМРАН** *и.* **1.** 1) Зур, юан агач кискәсе, утын түмәре. *Имән тумранын кисү уен-муен түгел шул.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин сап-сары сөяктәй нарат тумраннарының чәерле исе әчкелтем тузан диңгезендә йөзгән корабның каютасына, ягъни чарлак өйгә дә ничектер эләгеп калган.* Т.Нурмөхәммәтов

2) Агач бүкәне. *«Болар минем җизни булсамы?.. Мин яра алмаган тумранга болар калун белән бер генә суга инде», – дип уйлап куя.* С.Зыялы. *– Эчне бушатмагансың, киресенчә, тутыргансың бугай син, – дип төрттерде Сәбилә, тумран башындагы буш шешә белән стаканга күрсәтеп.* Р.Вәлиев

3) *диал.* Түмгәк. *Ә, әнә ич, читтәге тумран өстендә бер әсир ялгызы утыра.* М.Хуҗин

4) *күч. сөйл. тирг.* Аңгыра, миңгерәү (кеше яки хайван тур.). *Әйдә, әйдә, наа-а!.. Тумран. Дүрт аягың бар бит!* Д.Аппакова

**2.** *с. мәгъ.* Аңгыра, надан, миңгерәү, тинтәк. *[Хәлилов] биш процент югалтуның гади телгә күчергәндә нәрсә булганлыгын бу тумран башлы кешегә берничек тә төшендереп бирә алмый.* Ф.Хөсни

**ТУМРАНЛАП** *рәв.* Тумран (*1 мәгъ.*) рәвешендә; тумран-тумран итеп; тумран исәбе белән. *Бер атнадан бирле балаларның ата-аналарыннан тумранлап җыеп ягабыз.* Т.Гыйззәт

**ТУМРА́У** I *ф. диал.* Зур итеп кисеп ташлау (агач тур.). *Ир-атлар агачларны тумрадылар да ял итәргә утырдылар*

◊ **Тумраган да сөягән, балта-пычак тимәгән** *к.* **тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән**

**ТУМРА́У** II *и. к.* **тумран**. *Тумрау өстендә ике егет утыра.* Казан утлары

**ТУМСАРУ** *ф. диал. к.* **тумсаю**. *Һаман тумсарып йөреп булмый, кешедән оялырга кирәк бераз.* Сөембикә

**ТУМСАЮ** *ф. диал.* Үпкәләп яки ачуланып караңгы чырай күрсәтү, йөзне бозу, турсаю. *Тумсайганны кем яратсын, әйдә, онызт үпкәләреңне.* Сөембикә

**Тумсаеп тору** Әле, сөйләү моментында тумсаю

**ТУМЫРГА** *и. диал.* Кечкенә кыңгырау; шөлдер

**ТУМЫРКАБАШ** *и. биол. диал.* Тукранбаш. *Мин кайтканда, әби тумыркабашлар җыеп йөри иде.* Казан утлары

**ТУМЫРТТЫРЫП** *рәв.* Бик зур итеп, бик нык итеп. *Тумырттырып кисү. Тумырттырып кабу*

**ТУМЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тумыру**

2) Кармакка вак балык эләктереп, эре балык каптыру. *Кармакка вак балыкны эләктерәләр дә төнгә тумыртырга куялар.* Н.Фәттах

**ТУМЫРУ** I *ф. диал.* 1) Зур итеп кисү, кабу, өзү. *Аны тотып суюның, суйгач өтүнең, аннары итен иткә, салосын салога тумыруның җаен, әмәлен белергә кирәк.* Г.Рәхим. *Лукиян икмәкне бераз тумырып кабып җибәргәч, куенына тыгып куйды.* Ш.Камал

2) Аннан-моннан гына балта белән юну; тупас эшләү. *Андыйлар турында халык, умырган да тумырган, ди.* Идел

**Тумырып ату** Тиз-тиз тумыру. *Итне тумырып ату*

**Тумырып ташлау** *к.* **тумырып ату**. *Бу агачларны кем тумырып ташлаган?* И.Нуруллин

**ТУМЫРУ** II *ф. диал.* 1) Томыру, ыргыту, ташлау. *Тоягы җирне тумырган ---.* Дастан

2) *күч.* Кемгә дә булса бирү, тапшыру, сату, кирәксез әйбердән котылу. *Миндә, каениш, үтемле товарлар бар, шуларны берәр җиргә тумырып булмасмы?* Т.Гыйззәт. *Бу итәк-чалбарларыңны берәр кешегә тумырсаң да була иде инде.* Г.Галиева

◊ **Тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән** Тупас гәүдәле яки табигатьле кеше турында әйтелә. *Тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән бит аңа.* М.Мәһдиев. *Тумырган да сөягән, балтапычак тимәгән бәндә икән.* Н.Көбәш

**ТУМЫРЫЛУ** I *ф. диал.* 1) *төш. юн. к.* **тумыру** I. Зур итеп киселү; умырылу. *Хуҗалар тумырылган итләрне мунчала баулар белән чоланга асып куйганнан соң, дуңгыз өмәсенең эш өлеше тәмам була.* Г.Рәхим

2) *күч.* Аерылу. *Тумырылу җиңел түгел икәнне син беләсең дә, мин беләм.* Г.Ахунов

**ТУМЫРЫЛУ** II *ф. диал.* Бик тиз йөгерү; томырылу. *Яңа машинасында тумырылып кайтып та җитә ул, чакыр гына.* Г.Ахунов. *Тумырылып чапкан атка карап шаклар катты Гайфи.* Ә.Рәшит

**ТУМЫШ** *и.* **1.** Туу, дөньяга килү, яратылу, барлыкка килү. *Аның әтисе тумышы белән бу төбәктән.* Х.Камалов. *Кызыгыз тумышы белән бу якныкы түгел, ахрысы.* М.Маликова. *Майор абый Светаның әтисе икән, тумышы, чыгышы, килеше белән Себер татары булып чыкты.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Туган, дөньяга килгән, яратылган. *Һәр тумыш көнне үз әҗәлен көткән сырхау кебек, калтырап иза чикмичә, менә шулай, интекми-нитми яшәсәң иде икән!* М.Хәсәнов

**ТУМЫШТАН** *рәв.* Дөньяга килгән көннән, туганнан алып. *Белеп, максат итеп түгелдер, әлбәттә, тумыштан ук үтә нечкә күңелле, хискә бай кеше булгангадыр.* Х.Туфан. *Тумыштан күзләре кылый иде аның.* С.Юзеев

**ТУН** *и.* 1) Мехтан тегелгән җылы өс киеме. *Көнне җылыта төшсә дә, мине җылы тун вә киез итекләр көтсә дә, мин бүгенгә урамга чыга алмыйм.* М.Хуҗин. *Галиулла эшләрен бетереп кире керүгә, коридорда аны йоны тышка чыгып торган кара тун кигән бер чибәр генә яшь марҗа каршы алды.* З.Зәйнуллин

2) *иск.* Тышкы кием. *Багдад ягыннан килеп, Болгарда төпләнеп калган Габид атлы тегүчегә ул моннан өч ай чамасы элек --- кызыл атластан җәйге тун тектерергә биргән иде.* Н.Фәттах

3) *иск.* Гомумән кием. *Яңадан аяр җаным юк, судан аяр туным юк.* Әйтем

4) *иск.* Туйга киелә торган затлы кием. *Туе узган, туны тузган.* Әйтем

5) *күч.* Хайваннарның йоны, тиресе. *Тәкә тунын салдырдым, Шуны үзем ябындым.* Табышмак. *Кышкы ак тунын кигән куян икән.* Сабантуй. *Уйлап карыйк: җирне ак кар каплауга, ул [куян] соры тунын акка алмаштыра.* Кызыл таң

6) *күч.* Җир өстен, үсемлекләрне, корылмаларны каплаган кар, тузан һ.б.ш.лар катламы турында. *Әллә инде табигатьне сафлар өчен, көзен шәрәләнеп калган каен кызларына ак тунын кидерергә дип, әллә адәм балаларының күңелләрен агарту теләге белән, сөендерү максатында?* Ф.Яхин. *Чишмә үзе дә, ап-ак тунын ябынып, кышкы йокыга тала сыман.* Г.Әдһәм

**ТУНАЛУ** *ф. төш. юн. к.* **тунау**. *Кичә туналган пошилар тиресе дә ярап куйган.* М.Хәсәнов. *Җаны гына түгел, тәне дә начар хирург операция ясаганда үлеп киткән кешенеке кебек туналган, ямьсезләнгән иде.* Ф.Яруллин. *Таш юл тузаныннан туналып, шактый арып һәм таушалып, алар нәкъ кушылган көндезге дүрткә Әкчин вокзалына килеп җиттеләр.* А.Хәлим

**Тунала төшү** Бераз туналу; тагын да туналу

**Туналып бетү** Тәмам туналу. *Теге әйбер сыртына әйләнде һәм... су өстенә туналып бетмәгән эт тәпиләре тырпаеп килеп чыкты.* Р.Бәшәр. *Аның авыз эчләре, иреннәре туналып беткән иде.* М.Мәһдиев

**ТУНАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тунау**. *Мин аларның тиреләрен энә белән тунатырмын!* М.Галәү. *Озак та үтмәгән, бай, бер үгез суеп, аның тиресен тунаткан.* А.Алиш. *Сез, минем дүрт кат тиремне тунату артыннан йөреп, үзегезнекеннән яздыгыз.* Н.Исәнбәт

**Туната башлау** Тунатырга тотыну. *Тиресен туната башлау*

**Тунатып бетерү** Барысын да тунату; тунатуны төгәлләү. *Үгезнең тиресен тунатып бетерүгә, тиз генә җыендык та юлга чыктык.* И.Нуруллин

**Тунатып ташлау** Бөтенләй тунату; бик тиз тунату. *Черкиләрдән куркып, Сталинның Кара диңгез ярларында ничәшәр йөз ел үскән кипарисларны тунатып ташлатканын ишеткәне бар идеме хөрмәтле Иван Ивановичның, әллә Сталин белән холык уртаклыгы очраклы туры килдеме, тарихта бу мәсьәлә әлегә ачылмыйча кала бирә.* А.Гыйләҗев

**ТУНА́У** *ф.* 1) Берәр хайванның, җәнлекнең тиресен пычак ярдәмендә суеп салдыру, сыдырып төшерү. *Чирләп үлмәгән, димәк, тунайбыз да ашыйбыз [сарыкны].* А.Хәмзин. *Үзе берничә иптәше белән әле суынып та җитмәгән аюны тунарга кереште.* Р.Сәгъди

2) Тәнне, берәр әгъзаны җәрәхәтләү, тирене суйдыру. *Сәхинең акырган тавышы ишетелде: молотилка аның кулын иңбашына хәтле капкан да тунапмы туный, халык аһ итте, трактор сүнде.* Р.Батулла

3) Өлешләргә, кисәкләргә бүлү; кискәләү; йолку. *Әмма каен утынга кисәр өчен, себеркегә тунар өчен генә үсми ләбаса.* Т.Миңнуллин. *Ундүрт табаклык китапны сигез табакка калдыру өчен күпме тунарга туры килде кульязманы.* Ф.Яруллин

4) *диал.* Каезлау, сыдыру; артык әйберләреннән арындыру, шомарту. *Кемдер аның ботакларын тунап басма иткән.* М.Яһудин. *Бик озак сайлана торгач, Иттакый үзенең ярдәмчеләренә әмер бирде: – Менә бу җиләк агачын тунарга.* З.Мәхмүди

5) *күч.* Кыйнау. *Әгәр дә өстәл янында, кунаклар алдында берәр сүз ычкындырсагыз, ыштаннарыгызны салдырып, каеш чыбыркы белән тунармын.* Т.Миңнуллин. *Шуның өчен Мөхәммәт абыйлары аны, арбага бәйләп, каеш чыбыркы белән тунаган иде.* А.Хәлим

6) *күч.* Рухи яктан газаплау. *Әниеңне барыбер төрмәгә алып китеп, тунап үтерерләр иде.* Р.Рахман. *Әмма билгесез кеч үтмәс пычак белән йөрәген тунады.* Т.Галиуллин. *Егетләр, сез ишеттегезме, хуҗа кемне тунап китте?..* Ватаным Татарстан

7) *күч.* Кеше мөлкәтен һ.б.ш.ны рәхимсез рәвештә көчләп алу, талау. *Әллә кемнәрне өйдә калдырып, өеңне тунап чыгып китсәләр әле.* Казан утлары

8) *күч.* Берәр нәрсә өчен артык, чамадан тыш хак түләргә мәҗбүр итү. *Түләп, рәхәтләнеп барасы урында, ике кат тунадылар, өстәвенә, яңадан билетлар да алдырдылар.* Г.Ибраһимов

**Тунап алу** Тиз генә, тиз арада тунау. *Сары Каен, пычагын чыгарып, мәетләрнең баш тиреләрен тунап алды.* И.Хуҗин. *Шулай, өйрәнгән җитезлекләрен исенә төшерә-төшерә, гәүдәсе бигүк суынып өлгермәгән аюның тиресен елдам гына тунап алды Һадия.* Г.Якупова

**Тунап бетерү** Тунауны тәгәлләү; тулысынча, барысын да тунау. *Ниһаять, атның тиресен тунап бетерделәр.* М.Галәү. *Дөрес, беркайчан да тунап бетермиләр [түшкәне].* М.Мәһдиев

**Тунап карау** Сынау өчен тунау. *Рәхмәт, динозавр тунап карау кем бәхетенә тигән әле.* С.Зыялы. – *Ә дүрт аяклы малларны тунап караганым юк, – диде.* А.Хәсәнов

**Тунап ташлау** Тиз арада тунау. *Тик берүзем генә авылга караңгыда кайтып керсәм, әнкәй борчылыр, әткәй элек-электән үк күз алдында буталып йөргән дилбегә белән тунап ташлар!* Р.Гаязетдин

**Тунап тору** Гел тунау; сөйләү моментында тунау эшен башкару. *Мин килгәндә, ул бозау тиресен тунап тора иде, бик сөйләшеп булмады.* М.Мәһдиев

**Тунап чыгу** Барысын да тунау. *Һәммәсенең күзләре шар булган: ул Георгий кавалеры кайтсамы, ул бит шундук тунап чыга барчабызны!* К.Миңлебаев

**Тунап яту** *к.* **тунап тору**. *Нуркәй Садыйк кулакның йортына барып кергәндә, Садыйк кулак, дөрестән дә, караңгы гына бер урында сыер тунап ятадыр иде.* Һ.Такташ. *Лапас астында Хөбәйбулла кода белән Нигъмәтулла абзыкай түбән салындырып аскан бер зур сарыкны тунап яталар.* Ә.Еники

**Туный башлау** Тунарга керешү. *Авылның бар хатын-кызы, җыелып, балта белән куян тиресен туный башлаган.* Әкият. *Үткенрәк пычак китер әле, хәзер мин аны туный башлыйм.* З.Мәхмүди

**Туный тору** Әлегә тунау; нинди дә булса процесска кадәр тунау. *Дүрт баш сарыкның авызларын бисмилла тастымаллары белән уратып, мекердәтмимөгрәтмичә генә тыннары каткан алмагачлар аша мунча артына сөйрәттереп, берсе арты берсен чала, Гарифулла исә туный торды.* А.Хәлим

**ТУНГ** *и. кыт. бот.* Сөтлегәнчәләр семьялыгыннан составында тиз кибүчән майлар булган (аларны кыйммәтле техник майлар ясау өчен кулланалар) агулы орлыклы тропик агач; май агачы; *русчасы*: **масляное дерево, тунг**. *Тунг мае җитештерә торган иң зур фабрикаларның берсендә эшләде ул.* Казан утлары

**ТУНГУС** *и.* Эвенкларның элекке исеме. *Әнә шулай бу дәвердә татарларга һич булмаган яман гаеп-яла тагыла: иң әүвәл Идел буе болгарлары төркиләренә, ары таба мордва, тунгус, якут һәм хәтта Алтын Урда кул астында булган русларга да чаткысы җитә.* М.Хәбибуллин. *Тик менә әйт әле: ни өчен аның һәйкәленә тунгус килә, сахра дусты калмык, ягъни дә инде – монгол.* Ф.Яхин

**ТУНГУС-МАНЬЧЖУР** *и.* Ерак Көнчыгышта, Себердә яшәгән, телләре алтай семьясына караган нанай, эвенк, солон, эвен, ульта, маньчжур, чжурчжень һ.б.ш. халыкларның бергәлеге, гомуми исеме. *Ләкин төрки телләр белән монгол, тунгус-манчжур телләре яисә славян телләре белән грек, латин, герман, роман телләре тугандаш дип әйтү ни дәрәҗәдә хакыйкатькә туры килә икән?* Н.Фәттах. *Һәм кыргый татарлар – төньяктарак сунарчылык, балыкчылык һәм болан үрчетү белән көн күреп яшәгән тунгус-маньчжур кабиләләре.* И.Хуҗин

**ТУ́НДРА** *и. фин.* Җир шарының арктик поясы көньягындагы урмансыз, мәңге туң туфраклы, үсемлеккә бик ярлы табигый зона. *Шунда хатынының тундра ягыннан икәнлеген белдек.* М.Хәсәнов. *Шулай ук үсемлекләр капламы да үзгәргән, киң яфраклы урманнарны ылысылы урманнар алыштырган, ә бозлык кырыйларында тундра зонасы барлыкка килгән.* Р.Фәхретдинов

**ТУ́НДРА КАЗЫ** *и. зоол.* Үрдәк кошлар семьялыгыннан тундрада яши торган кечкенә башлы, кыска кара томшыклы, кара аяклы су кошы; казарка. *Тын океан киңлекләрен аркылыга-буйга иңләүче меңнәрчә кара тундра казы (кара казарка), Мексика һәм Калифорния ярымутравы тарафларын оныт ып, Аляскада кала башлаган ди әнә.* Ватаным Татарстан

**ТУНЕЦ** *и. гр. зоол.* Скумбрия балыклар семьялыгыннан җылы диңгезләрдә, океаннарда яши торган промысел балыгы. *Бер атна дигәндә, этнең бөтен рационы инде эшләнгән, кагыйдәләр ныклап урнашкан иде: --- каты ит бирмәскә, скумбрия урынына Тишкага тунец яки сайра бирергә һ.б.* М.Мәһдиев. *Сөякле балыкларга осётрсыман (укбаш, чөгә, кырпы), алабугасыман (алабуга, судак, тунец) --- һ.б. балыклар керә.* Хайваннар дөньясы

**ТУНИСЛЫ** *и.* Тунис халкы; шул халыкның вәкиле. *Безнеке шикелле лагерьлар янәшәдә әллә ничә. Бәреп кергәч, Карл тунислыларга шәфкать күрсәтмәгән.* В.Имамов. *Аларны кай арада төзеп өлгерткәннәрдер. Тотыклары: итальяннар, чехлар, французлар, греклар, алжирлылар, тунислылар һәм тагын әллә күпме халыклар.* Ш.Хәнифов

**ТУНЛЫК** *с.* **1.** Тун тегәргә яраклы, тун тегәргә җитәрлек. *Бигешкә ул бүләк итеп бер тәпән яңа бал бирде, бер тунлык иләнгән тире, хатынына дип пыяла муенса бирде.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Тунга дип билгеләнгән материал. *Инде ул мәһәргә килгән камзуллык, чатма тунлык, хәтфә, чук-чук энҗе димсең ---.* Ф.Халиди

**ТУННЕЛЬ** *и. ингл.* Бер яктан икенче якка үтәр өчен, җир астында, башлыча тауларда казып ачылган юл. *Шуннан тар гына туннель итеп алга табан туфрак ера башлады.* З.Мурсиев. *Кинәт юлны гигант кыя бүлде, һәм юл, озын туннель аша үтеп, хәзер инде Юпшара елгасы үзәненә җайлашты.* Д.Булатова

**ТУҢ** *с.* **1.** 1) Салкыннан, суыктан каткан, туңган. *Солдатлар чиратлап туң җир чабалар да кереп авалар.* Х.Камалов. *Яз көннәрендә туң булмаган җирләр суны үзенә күбрәк сеңдерә.* Р.Хәбибуллин

2) Күшеккән, өшегән. *Туң аякларның җылап булса да җылынасы килә, ә монда сиңа тиле шикелле авыз тутырып җырларга кушалар.* А.Хәлим

3) Тундырылган. *Кибеттәге туң балыкка алданып, боларны ташлап*

*китәмме соң!* Р.Вәлиев. *Пешерә торган ит сусыл булсын өчен, аны туң килеш кайнар суга салалар, ә аннары салмак утта кайнаталар.* Татарстан яшьләре

4) *күч.* Булдыксыз, надан, аңгыра. *Аларга шул чаттан әфьюн сатып утыручы Мөхәммәтҗан Хафиз һәм аның тирәсенә җыелган үзе шикелле туң карагруһчы итчеләр вә тиречеләр өреп калганнар.* Г.Тукай. *Хәлбуки бар андый көчләр, халык фикере белән бөтенләй исәпләшергә теләмәгән туң акыллы дәүләт идарәсе тармаклары.* З.Мәхмүди

5) *күч.* Мәрхәмәтсез, каты бәгырьле; хиссез, һәрнәрсәгә битараф. *Тукайның туң җаннарны да тетрәндерерлек шигъри юлларын гына алыйк.* Н.Хисамов. *Әмма туң бәгырьле ир дә салкын иде.* Н.Гыйматдинова. *Ләкин күңел усал, йөрәк туң икән, кан кардәшлек, туганлык онытыла да, адәм баласы үзенең иң якыннарының да явыз дошманына әверелә.* Безнең гәҗит

6) *күч.* Торгынлык хәлендәге, катып калган. *Мөселманлыкта сукырларча иярү, чиктән ашу, туң фикерлелек кебек эшләрнең һәрберсе тыелган.* Р.Фәхретдин. *Шул да эретмәсме туң бу заманны?* Р.Гаташ

7) *күч.* Саңгырау, тоник. *Сикәлтәләрдә, салулаган чакларда бер-берсенә бәрелеп, флөгәләр туң тавыш белән аваз биреп алалар.* Н.Әхмәдиев. *Солдатлар туң гына тавыш белән ура кычкырдылар.* Ш.Камал

8) *күч.* Төссез, нурсыз (күз тур.) *Томан аша Сәетнең туң күзләрен күргәндәй булды.* М.Кәбиров

**2.** *и. мәгъ.* 1) Салкын тәэсирендә туңган булу, туңганлык, катканлык. *Җирдә туң күп, балта белән чапмыйча булмый, көрәк керерлек түгел.* Г.Якупова

2) Җирнең тыгызланып туңган катламы, өлеше. *Юл тар, туң әле калын түгел, тик менә үзебезнекеләрнең генә иң соңгысын уздырырга иде.* М.Мәһдиев. *Шактый туң чокыйсы.* Ш.Галиев. *Ашамаганнар, талчыкканнар, лум белән туң төябез.* Р.Мөхәммәтшин

3) Салкын, суык. *Шуңа күрә байбакларга өннәрне тирән итеп, туң төшмәслек тирәнлектә казырга туры килә.* А.Хәсәнов. *Кар керерлек, туң үтәрлек булмасын.* Г.Сабитов. *«Ачысын туң суырган, кызык бу дөнья», – дип, үзенчә нәтиҗә ясады.* Ф.Җамалетдинова. *Керләрне туңга чыгарып элү*

◊ **Туң агач** *мыск. к.* **туң баш**. *Без туң агачларга ярый инде, син укыган кеше, син дә күтәрелә алмагансың кебек, ә?* Х.Камалов. **Туң аяк** *шелт.* 1) Чакырылмаган кунак. *Безнең якта миндәй чакырылмаган кунакны туң аяк дип йөртәләр.* С.Кудаш; 2) Күп йөргергә, кәеф-сафа сөрергә яратучы кеше. **Туң баш** *мыск.* Надан, аңгыра, зиһенсез, томана кеше. *Ә хуҗалар, туң башлар, төпчек җыярга махсус вәкил куярга искәрмәгәннәр.* А.Гыйләҗев. *Барысы да надан, барысы да туң баш.* Н.Фәттах. **Туң бүкән** *к.* **туң баш**. *Оятсыз, туң бүкән. Күзгә карап ни дип тора!* Ф.Яруллин. **Туң җан** *к.* **туң йөрәк**. *Ә безнең дөньяда бар икәнебезне дә белергә теләмисең, кабахәт, таш бәгырь, туң җан.* Р.Габделхакова. **Туң ишәк** *к.* **туң баш**. *– Яшәрмен, – ди [төлке], – мондый туң ишәкләр яшәгәндә дөнья йөзендә!* Ә.Фәйзи. **Туң йөрәк** *шелт.* Хиссез, дәртсез, салкын табигатьле кеше. *Ничекләр итеп җылытырга сабые салыначак бу туң җирне, аннан да бигрәк, бу дөньяның туң йөрәкләрен?* Р.Туфитуллова. *Чөнки андый туң йөрәкләр һәрнәрсәдә фәкать акча күрә, андый бәндәләрнең тәңкә дип миләре томаланган, шул ук тәңкә йөрәгенә пичәтен суккан була.* М.Хәсәнов. **Туң кәбестә күчәне** *к.* **туң күчән**. *Сез куып чыгарган теге туң кәбестә күчәне Назир бүлмәсендә сезне Зыяга әләкләп утыра.* С.Кудаш. **Туң колак** *сөйл. мыск.* Саңгырау, чукрак кеше. *– Әйттем бит. – Ә син, туң колак, җиңешкән буласың.* Г.Ахунов. **Туң күчән** *мыск.* 1) *к.* **туң баш**. *Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була...* Ә.Еники. *Бөтенләй үк туң күчән түгелме? Табигать хозурлыгыннан аз гына хәбәре бармы?* К.Тимбикова; 2) Кешелексез, кешеләргә салкын карашлы. *Әгәр бусы да тегесе кебек туң күчән булса, бүтән монда эшләмим, җитте, пенсиягә чыгам.* Ф.Яруллин. **Туң маңгай** *к.* **туң баш**. **Туң ми** *к.* **туң баш**. *Син ул атны кая апкитәсен беләсеңме суң, туң ми?* В.Нуруллин. **Туң морҗа** *к.* **туң баш**. *Их сез... туң морҗалар! Кая инде сезгә аңлау...* М.Шабай. **Туң тимер** *к.* **туң йөрәк**. **Туң тумран** *мыск. к.* **туң баш**. *--- туң тумран, тинтәк баш икәнсең!* Ш.Маннур. **Туң түмәр** *сөйл. мыск.* Эшлексез, надан кеше. *Туң түмәргә исебез китми.* Ф.Яруллин

**ТУҢБАШЛЫК** *и. сөйл.* Аңгыралык, томаналык. *Моннан да мәнсезлек, моннан да туңбашлык булырмы дөньяда?* Ш.Маннур

**ТУҢГАК** *с.* 1) Туңучан, өшүчән (кеше тур.) *Кышын ул туңгак, аңа кышын томау төшә, ютәлли башлый.* Р.Батулла

2) *к.* **туңгалак**. *Туңгак юлда шәһәргә бәрәңге ташыганда, дагасыз көйгә [атның] аягын яңадан авырттырдылар.* К.Басыйров. *Туңгак юлдан дыңгырдыңгыр озак бардык.* Сөембикә

**ТУҢГАЛАК** *с.* Бозланган, каты. *Язгы туңгалак кар*

**ТУҢГЫЗ** *и. диал.* Эшкәртелгән бүрәнәләрнең баш-башларын берберсенең өстенә куеп ясалган һәм шуңа салам, кабык һ.б.ш. материал җәелгән корылма; өй түбәсе чатыры

**ТУҢГЫ́З АЙРАВЫГЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан тармак-тармак чуклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **ежа сборная**

**ТУҢДЫРГЫЧ** *и.* Азык-төлек туңдыру өчен файдаланыла торган җиһаз яки суыткычның аерым япкычлы өлеше. *Ашханәдәге зур туңдыргыч та, мәктәптә куллану өчен алынган принтер да бизнес-планны үтәү нигезендә кергән акчага алынды.* Г.Гәрәева. *Җиренә җиткереп әзерләнгән итне туңдыргычта сакласаң, ел буе торса да бернәрсә булмый.* Л.Йосыпова

**ТУҢДЫРМА** *и.* Сөткә җиләк-җимеш суы, чикләвек, шоколад я башка төрле тәмләткечләр кушып туңдырып әзерләнә торган татлы ашамлык. *Ленин урамы буйлап барганда, Зәйтүнә туңдырма сатып алды.* М.Маликова. *Һәм кайгы белмичә, Кем туң-*

*дырма ялап йөри, ә кем сыра эчә.* Р.Мөхәммәтшин

**ТУҢДЫРУ** *ф.* 1) Өшетү, туңуга сәбәпче булу; туңарга мәҗбүр итү. *– Баланы туңдырмадыгызмы? – дип, Гөлшәһидә Юматша кулыннан баланы алды да битен ачып карады.* Г.Әпсәләмов. *Кулың салкын, беләкне туңдырды.* Н.Гыйматдинова. *Миләш тәлгәше кулны туңдыра.* А.Мансуров

2) Туң хәлгә китерү, катыру (җир, су һ.б.ш. тур.). *Бервакыт туңдырды. Урамда йөрерлек булды.* М.Мәһдиев

3) Саклар өчен катыру, туң хәлгә китерү (ит, балык, җиләк-җимеш һ.б.ш. тур.) *Габделбәр тотып килгән балыкларның күбесен кар өстенә салып туңдырдылар.* А.Хәсәнов. *Улым, суыткычта туңдырган карлыган бар.* М.Хуҗин

4) *з.-сыз* Салкыннан туң барлыкка килү. *Моннан өч-дүрт көн элек туңдырып, боз каткан иде.* Г.Бәширов. *Шулай да салкынча әле, кыш, календарьдан китсә дә, табигатьтән китәргә, бирешергә теләми: төннәрен туңдыра, уйламаганда җәяүле буран чыга, ышык, капланган урыннардан суык бөркелә.* С.Шәрипов

5) *з.-сыз.* Бизгәк тоту. *Гөлфиянең кымшанырлык та хәле юк, тиктомалдан гына баш әйләнә, бер яндыра, бер туңдыра иде.* Н.Гыйматдинова. *Тән температурасы бик нык күтәрелә (бу – авыруның төп билгесе), авыру эләккән кешенең мускуллары һәм буыннары авырта башлый, калтырата, туңдыра, күңел болгана, баш авырта, күзнең күрүе начарлана, күз алларында томан хасил була.* Шәһри Казан

6) *күч.* Тупасландыру; көчен, тәэсирен киметү, төссезләндерү; әрнетү (хисләр һ.б.ш. тур.). *Күңелгә салкын үрмәли, җыйналып, бөтен сүзләрне, тойгыларны туңдыра.* Ә.Баян. *Әшәке иде бу боздай салкын бушлык, йөрәгенә сарылып, бөтен уй-хисләрен туңдыра кебек иде.* Ә.Еники

**Туңдыра бару** Вакыт үткән саен ныграк туңдыру

**Туңдыра башлау** Туңдырырга тотыну. *Ә менә атышлар тынгач һәм караңгы төшкәч исә, җилекләргә үтеп туңдыра башлады.* В.Нуруллин. *Бераздан юеш туфли аякны туңдыра башлады, дымланып авырайган пальто иңбашларны аска тартты.* М.Маликова

**Туңдыра төшү** Тагын да ныграк туңдыру. *Ноябрь ахырларында, туфрак 5–6 см га кадәр туңдыра төшкәч, утыртылган түтәлләрне һәм участокта үскән күпьеллык яшелчәләрне мүлчәләргә кирәк.* Өмет

**Туңдырып алу** Аз гына вакыт аралыгында туңдыру. *Әнә шулай, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ул күлмәк җиңемне кайтарып күтәрде, шприц белән коралланып, беләгемә чәнчеде, боз тигәндәй, шул төшемне дару туңдырып алды.* С.Сабиров

**Туңдырып бетерү** Бик нык туңдыру; бар җирне дә туңдыру, барысын да туңдыру. *Тиз буласыңмы инде, Гөлшәһидә? Әхлетдинне туңдырып бетердең ич.* Г.Әпсәләмов. --- *үгетлиүгетли, кызны туңдырып бетерә инде.* К.Кәримов

**Туңдырып җибәрү** Бераз туңдыру. *Эш шунда ки, көз көне, җир туңдырып җибәргәч, әле кар төшмәс борын, безнең авылда дуңгыз сую өмәләре китә.* Г.Рәхим. *Җитмәсә, төштән соң җил, тротуар өсләрен боз япмага төреп, чытырдатып туңдырып җибәрә.* Д.Бүләков

**Туңдырып кую** Алдан ук туңган хәлгә китерү; кисәк туңдыру. *Нишләр идең, әгәр октябрь башында ук кар төшеп, туңдырып куйса?* Н.Әхмәдиев. *Таң атканчы яңгыры да, кары да явып китәргә мөмкин, көтмәгәндә генә шыкырдатып туңдырып та куя.* К.Кәримов

**Туңдырып тору** Туңдырган килеш тоту; әледән-әле туңдыру; даими туңдыру. *Ике-өч көн туңдырып торды да, каникулның соңгы көнендә кинәт җылы яңгыр явып, дөньяны су басты.* М.Мәһдиев

**ТУҢКА** *и. диал.* Калыпка салынган чи кирпеч

**ТУҢКАЙТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **туңкаю**. *Мәнә синең җәй буе чөгендер басуында артың туңкайтып чүп утап алган тимер-томырларың бернәрсәгә дә ярамый, диде.* Аманулла

2) Бүлтәйтү. *Кызыл билле прәннекләр, чуклы конфетлар, чикләвекләр ике як казаки кесәсен туңкайтып чыгарып тора.* М.Гали

**Туңкайтып кую** Туңкайган хәлгә китерү. *Ә туңкайтып куйган җирен нишләтсәләр дә ярый...* Э.Шәрифуллина

**Туңкайтып тору** Хәзерге вакытта туңкайту; озак вакыт дәвамында туңкайту. *Тунын әйләндереп кия дә, караңгы аралыкка кереп (сыерлары булмауга карамастан), бозау рәвешен китерә дә, артын туңкайтып тора.* Т.Нәҗмиев

**ТУҢКАЮ** *ф.* 1) Артны чыгару, артны сузу. *Сискәнгән сыман калкынып куйды да: – Туңкаю дигәннән, Мозаффар, карават асты юылмый калды бугай бит әле безнең.* Ф.Баттал. *Ишек катына килеп җитәрәк, гыйбрәтле күренешкә тап булды: алачык буенда яткан ялгашка башын куеп, туңкаеп, бер адәм мәсхәрәсе ята иде.* Г.Гыйльманов

2) Бүлтәю; төртеп тору. *[Гыйбаш абзый] аяк чалып маташкан бер малайның туңкаеп чыккан арт ягына салмак кына итеп таягы белән сукты.* Г.Бәширов

**Туңкаеп тору** Сөйләү моментында туңкаю; билгеле вакыт туңкайган хәлдә калу. *Ул әйтеп тә бетермәде, әле генә минем алда туңкаеп торган малай сикереп җилкәмә менеп утырды, башкалар аның артыннан тезелделәр.* И.Салахов

**ТУҢЛЫК** *и.* 1) Җир туң булу. *Күпьеллык туңлык ясалуның сәбәбен галимнәр кышның аз карлы, салкын һәм уртача еллык температураның 0° С тан түбән булуы белән аңлаталар.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Әмма сугыштан соң бөлгенлеккә төшкән ил өчен бу мәңгелек туңлык аша юлны төзү җиңел булмаган.* Кызыл таң

2) *күч.* Булдыксызлык, аңгыралык; наданлык

3) *күч.* Башкаларга карата мөнәсәбәттә каты күңеллелек, салкынлык. *Күңелләрдәге, фикер сөрешендәге, үзара мөнәсәбәтләрдәге туңлык, тарлык, көнчелек әле булса үз көчендә кала бирә.* Н.Фәттах

4) *күч.* Җәмгыять тормышындагы торгынлык, катып калу. *Кыскасы, бу календарьга кертелгән Акмулла шигыре һәм башка материаллар да төзүче тарафыннан бик оста сайлап алынган*

*һәм искелекне, иҗтимагый туңлыкны, катып калганлыкны җимерүгә, иҗтимагый алгарышка хезмәт иткән.* Җ.Миңнуллин

**ТУҢМАЙ** *и.* Иткә суелган сыер, бозау һ.б.ш. малның эченнән чыккан һәм эретелгән эч мае. *Мөхәмматханның капчыгында тире оек эченә тыгылган бер чирек сөт, суган, туңмай белән пешереп төелгән бәрәңгедән куш йодрык зурлыгында алты йомарлам һәм, алабута оны кушып пешергән, чынаяк тәлинкәсе зурлыгында нәкъ алты юка таба күмәче була иде – моның белән инде ачыкмаска була!* М.Мәһдиев. *Посылка эченә бер кием киез итек, ике пар йон оек, бер кисәк туңмай, калган ягына, тартма тулганчы, көздән суелган сарык ите салды.* Н.Кәримова

**ТУҢУ** *ф.* 1) Туң керү, салкыннан кату (җир, балчык һ.б.ш. тур.). *Юк, әнкәй, быел эшләп булганны нигә киләсе елга калдырырга, җир туңып беренче кар яту белән, урманга чыгып, агач хәстәрли башлыйм.* Г.Гыйльманов. *Сазлыклар күп бездә, шуңа юл туңгач, ягъни кыш көне генә, печән-саламны сөйрәтеп алып кайталар.* Х.Ширмән

2) Салкын, түбән температура тәэсиренә бирешү, суык сизү, күшегү. *Иртәгә туңып, катып, букчаларын күтәреп, балалар мәктәпкә җыелырлар.* Г.Исхакый. *Класста борын туңарлык салкын.* М.Мәһдиев

3) Салкында бик озак торып яки каты суыктан һәлак булырлык, үләрлек дәрәҗәдә өшү. *Алтмыш җиденче елның кышында, буранлап торган ачы салкын көнне күрше авылга барып, бик каты эчкән дә шуннан кайтып килешли туңып үлгән иде ул.* В.Нуруллин. *Былтыргы кышкы чилләдә аларның да ике тавыгы, безнең дә ике тавыгыбыз туңып үлде.* А.Хәлим

4) Боз белән каплану, бозлану; салкыннан бозга әйләнү, боз булып кату. *Әзрәк кенә исерә төшкәндәй чалыш-чолыш атлабрак, Пеләтән урамына чыктым, аннары Тукай урамына җитеп, тәрәзәләре агарып туңган трамвайга утырдым.* Ә.Еники. *Чөнки океаннар да туңып, Җир шары боз шарына, бәллүр табутка әйләнәчәк.* А.Тимергалин

5) *физ.* Билгеле бер температурага җиткәч кату (сыек яки газ хәлендәге матдәләр тур.). *Алдан кайбер компонентлар кушып, аның тыгызлыгы, суыкта туңу температурасы кебек күрсәткечләрен соляркага якынайтканнар.* Безнең гәҗит

6) *күч.* Хиссезләнү, дәртсезләнү. *Иң кыйммәтле җирдә – җан җылысы, җан җылысы җитми туңабыз.* Ф.Яруллин. *Беренче чын, гомерлек мәхәббәтен табу өчен, адәм баласы «мең янып һәм мең туңып, мең сокланып, мең уфтанып, мең үлеп һәм мең туып» яңадан туарга тиеш.* Т.Галиуллин

7) *күч.* Катып калу, торгынлык кичерү, үзгәрешсез хәлдә булу. *Әмма Рим Идиятуллин туңып калган шагыйрь түгел, Казанда һәм Уфада аның шигырьләре гәзит-журналларда әледән-әле чыгып тора.* Н.Нәҗми. *Без әдәбияттагы форманы туңган – абсолют бер төстә алмыйбыз.* Һ.Такташ

◊ **Туңган йөрәк** *к.* **туң йөрәк**. *Кабындырды кызның күз карашы Туксан яшьлек туңган йөрәкне.* М.Җәлил

**Туңа бару** Торган саен ныграк туңу. *Түбәләргә кыраулар төшеп, җир туңа барган бер вакытта, күрше йорт ихатасы белән үзебезнең капка стенасы почмагында карап торышка тәбәнәк кенә булган, әмма бик иркен эчле, берничә араталы сарай барлыкка килде.* Т.Нурмөхәммәтов

**Туңа башлау** Туңу билгеләре күренү. *Мәнә бераздан ул туңа башлар, башта кием бозланыр, аннан үзе.* М.Мәһдиев. *Толып эчендә булуына да карамастан, Гайния инде туңа да башлады һәм, үзе дә сизмичә, Мисбахка елышарак төште.* Н.Әхмәдиев

**Туңа тору** Шунда ук туңу; тиз арада туңу. *Тамчылар төнге күккә сибелеп, аннан тагы җиргә тама тора, туңа тора: кышын караңгы тау куышларында, язын-көзен өй түбәләрендә асылынып, күктән җиргә кадалырга торган боз сөңгеләр төсле укмаша.* Ә.Баян

**Туңа төшү** Тагын да күбрәк туңу; бераз туңу. *Аяклары туңа төшкән иде, чана юлыннан тая-тая атлый торгач, җылынып китте.* Д.Каюмова. *Әнә ул да, туңа төшкән кулларын җиң эчләренә тыккан килеш, минем кар белән шаяруымны күзәтә.* Яңарыш

**Туңып бару** Аз-азлап, әкренләп туңу; туңуга таба бару. *Еракта да җылытасың Туңып барган бәгырьләрне; Уятасың, ярсытасың Сулып барган шагыйрьләрне.* Н.Нәҗми. *Нурҗамал карчыкның сүнеп барган күзләренә җан кергән кебек булды, туңып барган йөрәге яңадан тибә башлады.* Ф.Бәйрәмова

**Туңып бетү** Бик каты туңу; тәмам туңу. *Диләфрүз урамда озак йөргән ахрысы, тәмам туңып беткән, дер-дер калтырый.* Г.Әпсәләмов. *Озак кына көтеп, өшеп, туңып беттеләр, чөнки март башы булса да, салкын, җилле көн иде.* З.Мәхмүди

**Туңып йөрү** Озак вакыт дәвамында туңу; һәрвакыт туңу. *Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышка суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде.* Г.Камал

**Туңып калу** Нинди дә булса тәэсирдән соң туңу. *Нәфисә исенә төшү белән, Зиннәт туңып калган күңеленең, язгы боз кебек, акрын-акрын эри баруын тоя башлады.* Г.Бәширов. *Табигать сурәтенә символлар килеп кушыла: «Тирән диңгезнең куәтле бураннары күтәрелеп, дәррәү туңып калган зур-зур дулкыннары, киң, берсе артыннан берсе тезелешеп киткән биек таулар».* Д.Заһидуллина

**Туңып килү** Акрынлап туңу. *Ул минем туңып килә торган күңелемә җылы салды.* Г.Исхакый

**Туңып китү** Кинәт туңу; билгеле бер моменттан соң туңу. *Бабасының бу сүзләреннән Гөлҗиһанның йөрәге өшеп, туңып китте, бер мизгелгә тибеше дә тукталып торды кебек.* Ф.Бәйрәмова. *Алтынчәчнең тар иңбашлары туңып киткәндәй бөреште, гәүдәсе кечерәеп калгандай булды.* М.Маликова

**Туңып тору** Озак вакыт дәвамында туңу; әле, хәзер туңу; туңган хәлдә булу. *Эчләрендә туңып торган боз да бар!* К.Тинчурин. *Менә бүген дә, кояш шактый нык кыздыруга карамастан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора ---.* Ә.Еники

**Туңып яту** Озак вакыт дәвамында туңу. *Ә мин тегендә көн саен су ташыйм, пычранганын чыгарып түгәм, кыш буе туңып ятмау өчен, машина-машина утын ташып, җәй буе диярлек кисәм, ярам.* Ф.Баттал

**ТУҢУЧАН** *с.* Бик тиз туңа, күшегә, салкынга бирешә торган. *Бигрәк тә тиз туңучан кәҗә, сарык бәрәннәрен (әле яңа туган бозауны да кертәләр).* Р.Мөхетдинова. *Бу аларда кан йөреше бозылган дигән сүз, ягъни кул-аяклар туңучан була.* Ватаным Татарстан

**ТУҢУЧАНЛЫК** *и.* Туңучан булу. *Аңа туңучанлык хас*

**ТУП** I *и.* 1) Резина һ.б.ш. сыгылма материалдан ясалып, каты әйбергә бәргәндә сикерә торган, гадәттә эче куыш шар. *Ике малай туп уйный.* Ш.Галиев. *Татарның кайвакыт артык дәрәҗәдә тырышып гамәл кылуы үзенең капкасына туп керткән кебек килеп чыга.* З.Мансуров

2) Озын көпшәле артиллерия коралы, пушка. *Азов ныгытмасын камап алып, эреле-ваклы туплардан атулар башланып китте.* Х.Гали. *Уйларга кирәк иде, син бит төзәүче – наводчик, мин бүкән куеп торучы, ягъни мәсәлән тупны коручы – заряжающий булам.* Ф.Сафин

3) Артиллерия снаряды, ядрә. *Бик күптән, инде әллә кайчан, Аит әллә бар, әллә юк чагында ук ул туп Нурисламга тимичә калган иде: тез астын озынборын тешләп, ул кинәт җиргә чүкте дә, туп, аның башы очыннан гына үтеп, яшел чирәмгә барып төште.* Г.Әпсәләмов. *Өсләрендә бомба да шартламый, туп та очмый, тылда әллә ни хезмәтләре юк, эшне солдат хатыннары, картлар, балалар алып бара.* Р.Корбан

4) *сөйл.* Артиллерия хезмәте. *Киләсе елга син солдатка китәсең. Синең кебек таза [егетне] тупка алалар.* А.Шамов

◊ **Туп азыгы** *к.* **пушка ите**. *Ә халык аңа кадәрге сугышларда ничек туп азыгы булса, бүген дә шулай ук булып кала бирә түгелме соң?* Казан утлары.
**Туп ите** *к.* **пушка ите**. *Сугыш алласы фашистлардан яңадан-яңа туп ите таләп итә.* Г.Әпсәләмов. *Сугышларда туп ите дә алар булды.* Р.Зарипов

**ТУП** II *и. иск.* Бер урында җыелып, өелешеп, тупланып тору халәте. *Атлар туптa булу. Көтүне тупка җыю*

**ТУП** III *иярт.* Атлап йөргәндә яисә берәр нәрсә җиргә төшкәндә чыга торган саңгырау тавышны белдерә. *Туп та туп, туп та туп. Берәр кайчан тынар микән бу тавышлар?* И.Гази

◊ **Туп итеп** Көтмәгәндә, искәрмәстән. *Уналты ел буе синнән башка ятим үссен дә, кеше булып җиткәч кенә, туп итеп ничек килеп керим мин анда?* Р.Вәлиев. *Хәзер менә туп итеп кайтыр да керер.* Г.Мөхәммәтшин

**ТУП-** *кис.* Кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Туп-тулы сандыкны күргәч, карчык куанычыннан нишләргә белмәде.* Әкият. *1907 елның сентябрь ае ахырында аны беренче булып каршылаган кеше – «Йолдыз» гәзитендә редакция-кантур мөдире, хисапчы Галим (Галимҗан) Әмирхан бу хакта болай яза: «Мәрхүм Тукай Казанга килгән көннәрдәге төсенә карап, туп-туры Тукай арыган, Тукайга яхшы тәрбия кирәк, яхшы ашау кирәк, яхшы һава кирәклеге күренеп тора иде».* Кызыл таң

**ТУПА** *с.* 1) Башы яки бер очы түгәрәкләнеп торган; очлы булмаган, тупыйк. *Офыкта бер болыт соргылт төтенгә әйләнеп яктырып китте, ул болыттан тупа борынын аска игән металл сигара аерылды.* А.Толстой. *Кукәйнең тупа башында аксым кабыкка тиеп тормый.* Зоология

2) Түгәрәк, җәенке. *Тупа әйбер булырга тиеш бу.* Әкият

3) Үтмәс, үткер түгел. *Тупа пычак белән кисеп газапланма инде.* М.Әмирханов

**ТУПАК** *с. диал.* 1) Түгәрәк, җәенке; очы ашалган. *Старшина Никодимов әйтмешли, «ядрёная вошь!» Башы япон пулясы кебек тупак, арт саны очлы, сырты кара.* З.Зәйнуллин. *Тупак танаулы, ияге астындагы җыерчыклы калын тиресе асылынып торган җанвар белән ничек очрашу, Казбек өчен үч алу хакында азагынача ныклап уйларга кирәк...* Кызыл таң

2) Үткер түгел, үткер булмаган, йөзе ашалган; үтмәс. *Борынгы төрки-уйгурларда кабиләгә хәбәр китерүче хәбәрче махсус билге итеп кулына билгеле сандагы тупак ук тотып килгән.* Р.Әхмәтьянов

**ТУПАКЛАНУ** *ф. диал. к.* **тупалану**. *Пычак тупаклану. Чалгы тупаклану*

**ТУПАЛАНУ** *ф. диал.* 1) Очы ашалу, түгәрәкләнү. *[Ул таякчыкны] очы тупаланган һәм шомартылган кадактан тузга басканда аны ертмаслык итеп ясыйлар.* Йорт эшләре

2) Үтмәсләнү, йөзе ашалу

**Тупалана бару** Торган саен ныграк тупалану. *Пычак тупалана бара*

**Тупалана башлау** Тупалану билгеләре күренү. *Балта тупалана башлаган*

**Тупалана төшү** Тагын бераз тупалану. *Балтасының тупалана төшүен күреп, Каюм сүгенеп куйды.* Казан утлары

**Тупаланып бетү** Тәмам тупалану. *Пычак тупаланып беткән*

**Тупаланып калу** Тупак хәлгә килү

**ТУПАЛЫК** *и.* Тупа булу; үтмәслек

**ТУ́П АРБАСЫ** *и.* Өстенә туп урнаштырыла торган стан; лафет. *Туп арбасыннан бушаган атларга атланып, кызылармеецлар Бакалтайга таба чаптылар.* К.Тинчурин

**ТУПАРТУ** *ф.* Очлы әйбернең очын тупа, үтмәс итү, түгәрәкләтү, ашату

**ТУПАРУ** *ф. диал. к.* **тупалану**. *Үлән ашый – теше тупара.* Табышмак

**ТУПАС** *с.* **1**. 1) Начар, ямьсез, түбән сыйфатлы яки зәвыксыз эшләнгән. *Аның янында кулдан эшләнгән тупас өстәл һәм искереп, «кабыргалары» ямалып беткән диван сыман нәрсә.* Х.Камалов. *Кайчандыр күңел түрендә йөргән романтика, батырлык, гүзәллек көн дә торып авыр, тупас күн итекләрне, авыр, тупас сырма-чалбарларны кию белән, тәмсез, туклыксыз тары боткасы, дөге боткасы чәйнәү белән алышынды.* Н.Фәттах

2) Килбәтсез, шыксыз, ямьсез. *Тыштан караганда тупасрак күренгән бу абзый үз дәресен шундый итеп аңлатты ки, дәреснең үткәнен дә сизми калдылар.* Ф.Зыятдинов. *Кем аны шушындый тупас, авыру, ташландык хәлгә китергән?* Р.Миңнуллин

3) Каты, кытыршы. *Сатып алды да, калын һәм шактый тупас киндер*

*капчыкка салып, өенә алып кайтты.* Ә.Баян. *Тупас тукымадан тегелгән кара зәңгәр чалбары, вак шакмаклы соры күлмәге тагын да бөгәрләнә төшкән.* Т.Әйди

4) Колакка ятышсыз, калын, каты, ямьсез (тавыш, көлү, сөйләшү тур.). *Шуңа күрә, кызларны аеруга, сержант тупас тавыш белән: – Әйдәгез, штабка киттек!* Н.Әхмәдиев. *Нииндидер ят, тупас тавыш кемнедер ачулана иде: – Кыбырсыма әле шулхәтле, өлгерерсең.* Р.Габделхакова

5) Дорфа, нәзакәтсез, тәрбиясез, әдәпсез. *Анда тупас тел, әмма һәр сүзе чын.* Х.Камалов. *Кирам агай шушы дорфа, тупас, тәкәббер бичәнең нәрсәсенә мөкиббән икән, я?* Н.Гыйматдинова

6) Культурасыз. *Мәрьямне тупас мужик кызлары белән катыштырмаска, уйнатмаска тырышты.* Г.Ибраһимов

7) Гади, талымсыз. *Дөрест, минем тормышым түбән, тупас һәм простой булыр.* Г.Ибраһимов

8) Күзгә күренеп торган, кагыйдәне нык бозган, һич нормага сыя торган түгел. *Әгәр сез тәрҗемә иткәндә шундый тупас хаталар ясасагыз, әсәрнең эчтәлеген үзгәртүегез һәм бозуыгыз мөмкин.* Һ.Такташ. *Хәрби-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән эш итүдә тупас хатага юл куелды.* Я.Шәфыйков

9) Үткер булмаган, үтмәс, тупа. *Шул чакны искәрмәстән аның аркасына авыр, тупас нәрсә килеп төште.* Н.Фәттах. *Хәзер ул чирәмлекләр тупас төрән белән аннан-моннан сукаланган, аларга ашлама дип агу мул сибелгән ---.* Р.Фәйзуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Нечкәләп тормыйча, килешсез рәвештә; аннан-моннан, сыйфатсыз итеп. *Тупас эшләнгән өстәл-урындык*

2) Дорфа, әдәпсез рәвештә; нәзакәт сакламыйча. *Ничек син председатель кебек председательгә шулай тупас мөрәҗәгать итәсең?!* Р.Батулла. – *Мин Нәсим түгел, – диде ул тупас кына.* М.Кәбиров

**ТУПАСЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тупаслану**. *Үткән гомернең билгесезлеге хисләрне шулкадәр үзгәрткән, аның нечкә кылларын тупасландырган күрәсең.* Н.Әминов. *Кеше аңламаслык катлаулы чагыштырулар, катлаулы сурәтләүләр җырны авырайта, ятлап булмаслык тупасландыра.* Ф.Яруллин

**Тупасландыра бару** Торган саен ныграк тупасландыру. *Мондый гамәлләр җаныбызны тупасландыра бара.* Т.Миңнуллин. *Акчага табыну кешене тупасландыра бара, бу хакта хәтта галимнәр дә язып чыкты.* Ватаным Татарстан

**Тупасландыра башлау** Тупасландырырга тотыну. *Яңа эш сине тупасландыра башлады кебек.* Т.Галиуллин

**Тупасландыра төшү** Бераз тупасландыру. *Мәскәүдә яшәү аны тагын да тупасландыра төште.* Казан утлары

**Тупасландырып бетерү** Вакыт үткән саен күбрәк тупасландыру, тәмам тупасландыру. *Шәһәр кешене тупасландырып бетерә.* Ф.Яруллин. *Ләкин балтаның инде исеме генә үткер иде, үзе юк чакта аны тупасландырып бетергәннәр иде.* Н.Фәттах

**Тупасландырып тору** Тупас итеп күрсәтү, тупаслык бирү

**ТУПАСЛАНУ** *ф.* 1) Йомшаклыгы, эластиклыгы, сыгылмалылыгы бетү. *Борылышларда әрле-бирле килгән үтәли җил белән аның бит-йөзе ашалып тупаслана, йодрыклары рәхимсез урам сугышларында ныгый.* С.Юзеев

2) Үтмәсләнү, үткерлеген югалту; очы, йөзе ашалу. *Имән агачына керә алмаган йомшак балта кебек ул: балтаның йөзе әйләнеп чыга, тупаслана, имән исә, берни дә булмагандай, шаулап утыра бирә.* М.Мәһдиев. *Адәм җаннарын рәхимсез кыя-кыя, кылыч йөзләре тупаслана.* М.Галиев

3) Тышкы нәфислеген, матурлыгын югалту; ямьсезләнү, килбәтсезләнү, юанаю. *Бармаклар калынаеп тупасланды, билгеле.* Н.Гыйматдинова. *Җилдә, кояшта йөреп, авыр крестьян тормышында гәүдәләре тупасланган авыл хатыннары арасында Катерина нәфис-нәзакәтле йөз чалымнары, сылу гәүдәсе белән аерылып тора.* Г.Даутов

4) Әдәплелеге, нәфислеге, эчке рухи нәзакәтлелеге югалу (хисләр, күңел, холык һ.б. тур.). *Бәлки, олыгайган саен, матурлыкны тою хисе тупасланадыр.* Ф.Яруллин. *Гүзәлиянең холкы да кояш белән болыт: хәзер генә көлә, хәзер генә елый... Бер нечкәрә, бер тупаслана.* Н.Гыйматдинова

5) Әдәпсезләнү, тәрбиясезләнү, әдәпсезлек күрсәтү. – *Сабыйланма! – дип тупасланды Васфия. – Башыңа кирәкмәс уй тутырма!* М.Хуҗин. *Җәбир, үткәне турында сөйләшкәндә, ни өчендер үртәлде, тотлыкты, тупасланды һәм гомумән үзен бик сәер тотты.* Н.Фәттах

6) *күч.* Начар якка үзгәрү, ямьсезләнү, начараю. *Язуын язармын да бит, ләкин дөнья тупасланып, кешеләрнең шактые оялу һәм гарьләнү кебек хисләрдән мәхрүм калган бу заманда аңламаучылар да күп булыр кыйссамның монысын...* Ф.Баттал

**Тупаслана бару** Вакыт үткән саен ныграк тупаслану. *Биредә Туфанны киләчәккә өмет югалу, күңел тынычлыгы булмау, адәм рухының ярлылана, тупаслана баруы борчый.* Т.Галиуллин. *Тик түрәләрнең үз-үзен тотышлары көннән-көн тупаслана бара.* Безнең гәҗит

**Тупаслана башлау** Тупаслану билгеләре күренү. *Бу инде тойгыларның тупаслана башлавы түгелме икән?* Г.Бәширов. *Кызның туктаусыз бөтерелеп йөрүе аларның тупаслана башлаган күңелләрен нечкәртеп җибәрде.* Ф.Яруллин

**Тупаслана төшү** Бераз тупаслану; тагын да тупаслану. *Хаҗи аның янына якынайды. Хатынның авыр эштән тупаслана төшкән, хәтсез яргаланган уң кулын ике учына алып, туктаусыз селкеп, озак кына җибәрми торды.* Ә.Моталлапов. *Тик каләм дә тупаслана төшкән, инде бераз язгаларга мөмкин булыр дип уйлыйм.* Ә.Шамова

**Тупасланып алу** Кыска вакыт эчендә генә, аз гына тупаслану. *Гатауллин Алсуның тупасланып алуына игътибар итмәде.* Ф.Яхин

**Тупасланып бетү** Бөтенләй тупаслану; бик нык тупаслану. *Сугыш чорында ирләр урынына җигелеп, үгезләргә, атларга акырып тупасланып беткәч, Зөлхый дигән кушамат такканнар ие, ябышты да калды.* И.Юзеев. *Эшләгән урыны «юләрләр йорты»нда үлемкитемне, башка хәлләрне күп күрүдән бәгыре тупасланып беткән ул агай*

*дөнья хәлләренә исе дә китмәстән һаман сөйли бирде ---.* Ф.Яхин

**Тупасланып калу** Нәрсә тәэсирендәдер тупаска әйләнү. *Әле менә шушы утрауда, яшьлектә сөйгән ярының исемен ишеткәч, моңа кадәр тупасланып калган тойгылар кабат уянды.* М.Кәбиров. *Ул күргән-белгән авыл кешеләре картаебрак киткәннәр, урамнар да бераз ятсынылган, су буендагы өянкеләр дә тупасланып калган.* А.Хәмзин

**Тупасланып китү** Кисәктән яки берәр вакыйгадан соң тупаслану. *Бу хәлләрдән соң, билгеле, Әлфиянең күңеле тупасланып китте.* Казан утлары

**Тупасланып тору** Озак вакыт дәвамында тупаслану. *Иптәшең бу арада тупасланып тора ахры, бер-бер хәл булдымы әллә?* Сөембикә

**ТУПАСЛЫК** *и.* 1) Эшләнеше, сыйфаты, материалы тупас булу. *Киеменең тупаслыгы сәбәпле, күңеле сынык иде.* К.Насыйри

2) Тупас сүз, тупас кыланыш; дорфалык, әдәпсезлек. *Кайчакта тупаслык булып күренә торган кискенлеге, дөреслекне күзгә туры карап әйтә торган гадәте өчен, билгеле, кайберәүләр аны бик үк яратып та җиткермәделәр.* Н.Фәттах. *Ярлтканыннан мондый тупаслык көтмәгән иде егет, агарынып китте.* Р.Габделхакова

**ТУПАССЫНУ** *ф.* Тупас дип санау, тупас дип табу. *Күлмәк тукымасын тупассыну*

**ТУПА́У** *ф. диал.* Кыйнау, тукмау. *Хайванны тупау*

**ТУПИ́К** *и. рус* 1) Бер очы ябык тыкрык; үтә алмаслык киртәгә килеп терәлгән юл; сукыр тыкрык. *Кая барганыңны белми барсаң, шулай тупикка да килеп чыгасың инде ул.* И.Гази

2) Бер читкә кереп терәлгән тимер юл тармагы. *Тупикларга тимер юл цистерналары белән ракета ягулык-окислительләрен кертә башладылар.* Ә.Хәсән. *Тимер юл станциясендәге бер тупикта болар кукуруз чәкәннәре төялгән составка тап булдылар.* Ф.Зыятдинов

3) *күч.* Чишелеше булмаган кыен хәл, чарасызлык (тормыш, сәясәт һ.б. тур.). *Хәзерге юл – тупикка илтә торган юл ул.* Ш.Хәнифов. *Тормышының авыр, тупикка кергән вакытларында әти кычкырып җырлап ала иде.* М.Мәһдиев

**ТУ́ПИК** *и. зоол.* Ишкәкканатлылар семьялыгыннан ике яктан бик нык кысылган һәм үрчү вакытында матур ачык төскә керә торган зур томшыклы диңгез кошы (гадәттә, төньяк диңгезләрдә очрый); диңгез тутые

**ТУ́П ИТҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсә җиргә төшкәндә яки атлап йөргәндә саңгырау тавыш чыгару. *Һаман догадан бушаганы юк иде, күрде: өенең төнлегеннән ике капчык алтын туп итеп төште.* К.Насыйри. *Йомшак кыска чәчле, караеп килгән матур кашлы чандыр малай яланаяклары белән туп итеп идәнгә басты да, йокылы күзләрен уа-уа, Хәмдия апасы янына килде, күрешмәкче булып, чыбыктай беләген сузды.* Н.Фәттах

2) Егылу (балалар телендә). *Кызым, туп итмә бүтән, яме?* Сөембикә

3) **туп итеп** *рәв. мәгъ. к.* **тупырдап**. *Ә бит аның сөекле хатыны, туп итеп торган ике малае бар.* М.Кәбиров

**ТУПЛАВЫК** *и.* Су буенда малтуар, көтү җыела, туплана торган урын; туплау. *Төшкелектә елга буена, туплавыкка килгәч, кайберләре тиз арада суга керергә ашыкса, икенчеләре комда кызынырга ярата.* Ә.Баян. *Аларны пиратлар аргы туплавыктан чәлдергәннәр иде.* А.Тимергалин

**ТУПЛАМ** *и.* **1.** 1) Төркем булып, бер-берләренә бик якын басып торган кешеләр. *Без, кулга-кул тотышып, тыгыз туплам булып басып торабыз.* Казан утлары

2) Эзлекле рәвештә урнаштырылган текстлар, мәгълүматлар җыелмасы. *Бу тупламдагы дәфтәрләргә күз салу белән, аларның төрле кешеләр тарафыннан язылганлыгы ачыклана.* Л.Җамалетдинов

3) Билгеле бер темага караган, бер үк жанрдагы әдәби әсәрләр; цикл. *Мирҗакып Дулатлы исемле казах мәгърифәтчесенең ике тупламнан торган сайланма әсәрләре белән таныштым.* Р.Рахман. *Шулай да галимнең гомер буе җыйган ядкәрләрен бер туплам итеп бастыруы – үзе бер олы вакыйга, шуңа да киләчәктә аның зур тираж белән чыгуына өмет итик.* Л.Кәшфиева

4) *к.* **туплавык**. *Ыкның ярларын таптатма, терлекләргә теләсә кайда су эчермә, тупламда гына, бер генә урында, ташлыкка гына төшер.* Г.Бәширов

5) Ерткыч хайваннар яки маллар көтүе, төркеме. *Көтү туплам булып яткызлыкка урнаша.* Р.Батулла

6) *геол.* Бер урынга күп булып оешкан, туры килгән матдәләр, минераллар һ.б. *Минераллашкан цеолит туплам киселе буенча тигез таралган һәм өске катламнарга караганда шактый аз.* География. *Юылган фосфоритлы конгломерат – брекчий өслегендә дүртенче туплам – балчыклы бурташ ята.* Фән һәм тел

7) Капитал, матди байлык. *Туплам сүзе бүгенге көндә массакүләм мәгълүмат чараларында «капитал», «матди байлык» мәгънәсендә дә кулланыла.* М.Юматова

**2.** *с. мәгъ.* Тупланган, туплана торган. *Булачак пенсиянең туплам өлешен дәүләт Пенсия фондынамы, әллә дәүләтнеке булмаганына ышанып тапшырыргамы?* Ватаным Татарстан. *Теге биш туплам документка исемлек әзер иде.* Безнең гәҗит

**ТУПЛАМА** *и.* **1.** *к.* **туплам 1.** (*2, 3, 5 мәгъ.*). *Көндәлек матбугат басмаларында даими рәвештә дөнья күреп килгән саллы тупламаларында шагыйрьнең тагын да киңрәк офыкларны колачлавы, тирәнрәк катламнарга үтеп керүе, зуррак гомумиләштерүләргә ирешүе сизелеп тора.* Р.Вәлиев. *Аның портфолиосында (мактау кәгазьләре тупламасы) соңгы өч елда җыелган җиңүче дипломнары саны иллелән артты.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ. к.* **туплам 2.** *Ә пенсиянең калган страховка һәм туплама өлешләрен дә алу өчен, кешенең үз гаризасы кирәк булачак.* Татарстан яшьләре

**ТУПЛАН** *и. бор.* Бер төркем атлы гаскәр. *Тай менсәң, тупланга кермә.* Мәкаль

**ТУПЛАНГАНЛЫК** *и.* Оешканлык, үздисциплина. *Аңа уңышлы эш, оешканлык һәм уртак эш хакына тупланганлык телисе генә кала.* Ф.Галимуллин.

*Без белгәннән бирле бер дә үзгәрми ул: шул ук төз, мәһабәт гәүдә, җитез хәрәкәтләр; шул ук хәрбиләргә хас җыйнаклык, тупланганлык.* Дуслык

**ТУПЛАНМА** *и.* 1) Бер урынга күп итеп җыйналган, тупланган әйберләр, предметлар. *Тауларда урнашкан авылларда йөреп өйрәнеп, бөртекләп башкарылган фольклор тупланма бу.* Шәһри Казан. *Бу көннәрдә ул күренекле җырчы турындагы видеоязмаларны бер тупланма итеп әзерләү белән шөгыльләнә.* Казан утлары

2) *к.* **туплам 1.** (*5 мәгъ.*). *Ул районда газ тупланмалары күп булуы күптән мәгълүм иде инде.* Г.Ахунов

**ТУПЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **туплау**. *Идел кичүләрендә уңъяк ярга (ягъни Кырым тарафына) чыгар өчен торган саен күбрәк кәрван, тирмә, терлек көтүләре килеп туплана.* Г.Гарифуллин. *Хаҗга баручы мөселманнарның туплану урыны Уфа Диния нәзарәтендә булды.* Безнең гәҗит

2) Төркем булып оешу, җыелу (коллектив, көтү тур.). *Мондый кешеләр Осириснең энесе Тифон тирәсенә тупланалар һәм Осириска каршы төрле хәйләләр кора башлыйлар.* Н.Фәттах. *Әлегә без биредә оешу, туплану белән мәшгуль, эшебез башлангыч этапта гына.* Шәһри Казан

3) Аз-азлап, акрынлап җыелу, өстәлү, арту (белем, фикер һ.б.ш. тур.). *Шулай тормыш тәҗрибәсе туплана, кеше яшәргә өйрәнә.* Ф.Ганиева. *Тәҗрибә дигән нәрсә эшли һәм даими рәвештә өйрәнә торгач кына туплана бит.* Ә.Хәсән // Теге яки бу микъдарда җыелу. *Байлык аерым кешеләр кулына туплана.* Ф.Яруллин. *Электрон мәгълүматлар туплана.* Х.Миңнегулов

4) *күч.* Теге яки бу сыйфат һ.б.ш. бер объектка хас булу, шунда чагылу. *Шул кыйшайган мәктәп аңар бер мәркәз төсле тоела, авылның бөтен рухын ул монда тупланган шикелле күрә.* Ш.Камал. *Аның ирексездән туган бу хәрәкәтендә шул хәтле нәфрәт, шул хәтле ачу тупланган иде.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Уртак эш өчен берләшү, оешу, күмәкләшү. *Дөньяда бит славян халыклары да, инглиз телле халыклар да, глобализация чорында бер-берсен яклау өчен, шулай бергә туплана.* Р.Вәлиев. *Ярар ла мин беләм: ассоциация безнеңчә берләшү, җыйналу, туплану дигәнне аңлата.* Татарстан яшьләре

6) *күч.* Бөтен игътибар, эшчәнлек берәр нәрсәгә юнәлдерелү. *Татар опера театрының бинасын алдагы елда тәмам салып бетерүгә бөтен көч тупланырга тиеш.* М.Җәлил. *Әсәрдә бөтен вакыйга татар мещаннарына гына хас булган бирнә күлмәк тирәсенә тупланган.* М.Гали

**Туплана бару** Вакыт үткән саен күбрәк туплану. *Әмма, хайван булса да, күрәсең, бөтенләй аңсыз нәрсә түгел иде: эчендә ачу туплана барды аның.* Ф.Яруллин. *«Зур шартлау»дан соң яшерен материя туплана барып, аңардан галактика, аннары планеталар ясалган.* Ф.Хәбибуллин

**Туплана башлау** Тупланырга тотыну. *Менә шуннан соң сүз аеруча җитдиләнеп, спектакльне репертуардан алу хакында фикерләр туплана башлый.* К.Тимбикова. *Безнең милли гаскәребез туплана башлады.* Ф.Яхин

**Туплана килү** Озак вакыт дәвамында әз-әзләп туплану. *Шул мизгелдән еллар дәвамында акрынлап күчә, туплана килгән һәм көчәя барган эчке егәр Шагыйрьнең үзе белән очрашкан мәлгә инде ниндидер бер критик ноктасына җиткән булгандыр күрәсең.* М.Вәлиев

**Туплана тору** Әкренләп, аз-азлап, эзлекле рәвештә туплану. *Еллар үткән саен, бу кеше турындагы мәгълүматлар аз-азлап булса да туплана торды.* Р.Мостафин. – *Син, энем, эшлә әле әйдә, тәҗрибә дә туплана торыр,* – *диде Миркасыйм абый.* Казан утлары

**Туплана төшү** Тагын да ныграк, күбрәк туплану. *Ял вакыты җиткәнче акча тагын да туплана төште.* М.Мәһдиев. *Ул арада балтачылар да аякка басты, Җәбир тирәсенә туплана төштеләр.* Н.Фәттах

**Тупланып бару** Даими рәвештә, һәрдаим туплану. *Аның акчалары кенәгәдә тупланып барган.* М.Мәһдиев. *Мәгълүм булганча, эшләүче кешеләрнең булачак пенсияләренең бер өлеше дәүләтнеке яки дәүләтнеке булмаган пенсия фондларында тупланып бара ---.* Татарстан яшьләре

**Тупланып бетү** Тулысынча, тәмам туплану. *Шулай да, әдип калдырган мирас тулысы белән тупланып беткән дип әйтеп булмый әле.* Фән һәм тел. *Ягъни юмор уйнаучылар бер идея тирәсенә тупланып бетеп, --- тамаша сценарийларын иҗат итеп торуы кирәк.* Татарстан яшьләре

**Тупланып җитү** Кирәкле, тиешле дәрәҗәдә туплану. *Театр уены уйнарга хыялланучы яшьләрнең тәмам тупланып җитүенә ул пьеса бер этәргеч була.* Л.Хәмидуллин. *Төркем тупланып җиткәч безгә хәбәр итегез әле дип, телефон номерымны калдырдым.* Сөембикә

**Тупланып килү** Озак вакыт дәвамында тупланган булу. *Икенче төрле итеп әйткәндә, якын арада яңгыр буласын ачыклау әлләни кыен да түгел икән: халык күңелендә йөзләрчә-меңнәрчә еллар дәвамында тупланып килгән сынамышлар әлеге сорауга ярыйсы ук төгәл җавап бирә.* Ф.Урманчеев. *Аңлашылганча, басмабызның төп максаты халкыбызның гасырлар дәвамында тупланып килгән асыл мирас сандыгын ачып, андагы хәзинәне барлау, дөньяга күрсәтү белән бергә, аерым кешеләрнең үз күңелендә генә сакланган җәүһәрләрне уртак сандыгыбызга сала бару.* И.Иксанова

**Тупланып тору** Даими туплану; хәзерге вакытта тупланган булу. *Аннан соң бүгенге һава торышы да авыл хуҗалыгы өчен уңай тора, әлегә кырлар кардан арынмаган, димәк, кояш нурлары астында туфрактагы дым запасы бетми, киресенчә, кар астында тупланып тора.* Туган як

**ТУПЛАНЫШ** *и.* **1.** 1) Туплану (*1–2 мәгъ.*) эше, гамәле, процессы. *Фәүзияләр, Хәкимнәр, Фәндәсләр, ТИҮ, «Мөстәкыйльлек комитеты» янына тупланыш кирәк, хөрмәтле зыялылар.* Р.Батулла. *Икенчедән, мәхәлләгә оешу шартлары ифрат дәрәҗәдә катлауландырылган, бигрәк тә шәһәр шартларында: милли оешуның хокукый нигезләре юк, авылларда татар шактый гына оешып яшәсә дә, шәһәрләрдә милли тупланыш юк дәрәҗәсендә.* И.Әмирхан

2) *икът*. Туплану дәрәҗәсе, туплау эшенең торышы. *Билгеле, хөкүмәт ел саен гражданнарга ул акчаларның саклanышы, инфляция исәбеннән чыгып югарырак процентлар белән арта баруы, счётларындагы акча тупланышы турындагы мәгълүматны җиткереп баруны үз өстенә алырга тиеш, монысы – бәхәссез.* Татарстан яшьләре

3) Бер урынга, бер тирәгә җыелган кешеләр төркеме. *Мондагы тупланышларда милли һәм дини кичәләр дә үткәрә идек.* И.Мансуров // Аерым бер урынга, җиргә җыелган төрле әйберләр. *Истәлекнең гомуми анализы Никон җыентыгы тупланышын Мәскәү митрополиты кафедрасы белән бәйләргә мөмкинлек бирә.* Б.Хәмидуллин. *Бәвел куу эффектына ия рәйхан бәвелдәге тозлар тупланышын киметә һәм шул рәвешле бөердә таш барлыкка килүдән саклый.* Мәдәни җомга

4) Милли керемнең җитештерүне киңәйтүгә тотылган өлеше. *Федераль үзәк 2020 елга кадәр илебезнең автомобиль сәнәгатен үстерү концепциясен эшләүдә бик зур бурыч куйды: Россиядә сатыла торган машиналарның 80 процентка кадәре нәкъ менә безнең илдә җитештерелергә, автомобиль җитештерүнең тупланыш дәрәҗәсе 50 процентка җиткерелергә тиеш.* Ватаным Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җитештерүне киңәйтү өчен билгеләнгән. *Тупланыш фонды*

2) Җыела, туплана бара торган. *Бу пенсиянең тупланыш өлешенә бигрәк тә кагыла.* Кызыл таң

**ТУПЛА́У** I *ф.* 1) Төрле җиргә таралган, сибелгән, чәчелгән яки аерым-аерым урнашкан җанлы-җансыз нәрсәләрне, кешеләрне бер урынга, бер тирәгә җыю. *Һаҗәр шатлыгыннан су янына йөгерә һәм, як-якка таралып барган суны бер җиргә туплау өчен, тирәюньдәге ком-ташларны өеп куя.* Шәһри Казан. *Шул ук вакытта төзелеш материаллары туплау өчен махсус мәйданчык әзерләү дәвам итә.* Кызыл таң

2) Кешеләрне берәр кеше яки оешма тирәсенә җыю, тарту. *2013 елда Казанда үтәчәк XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасына волонтёрлар туплау эше тулы көченә башланып китте.* Шәһри Казан

3) Аз-азлап, акрынлап, берәмләп җыеп, үзендә булдыру. *Җәй көне әз булса да көч туплап, ял итеп калына иде.* Ф.Яруллин

4) Төрле кешеләрдән, төрле чыганаклардан нинди дә булса сүз, хәбәр һ.б.ш.ны җыю, алу. *Боларны санап чыгу җиңел булса да, эзләп табу һәм китап каһарманы булырлык мәгълүмат туплап язуның кыенлыгын аны эшләп караган кеше генә аңлыйдыр.* Р.Шәрәфиев. *Әсәрне татар кешесенә генә хас, күзгә, зиһенгә бәрелеп, мөгез төсле алга чыгып тормаган, бөртекләп җыйналган үзенчәлекләрне, гасырлар түрендә бөреләнгән сыйфат-билгеләрне туплап, саклап, безгә китереп җиткергән олы җанлы, гадәти кешеләр бизи.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Теге яки бу максат өчен берләштерү, оештыру. *Нигә безнең Журналистлар берлеге матбугатның отырыы хөртиләнә барган хәленә карата мөнәсәбәтен белдереп чыгыш ясамый (каләмдәшләрне туплап урамга чыгу турында әйтмим дә), пенсиядәгеләр тормышы белән кызыксынмый?* Р.Шәрәфиев

6) *күч.* Барлык көч, фикер, уй, сәләт һ.б.ш.ны билгеле бер эшкә, максатка юнәлдерү. *Шулай да, бар ихтыяр көчемне туплап, карашымны автобус эчендәге реклама кәгазьләренә юнәлттем.* Казан утлары

**Туплап бетерү** Барысын да туплау; җитәрлек дәрәҗәдә туплау. *Әмма ни сәбәпледер икенче елны аны ярышларга чакырмыйлар: әллә район командасын туплап бетерә алмыйлар шунда, әллә Дилбәргә Казаннан чакыру җибәрергә оныталар.* Татарстан яшьләре

**Туплап кую** Алдан ук туплау; тиз арада туплау. *Әле дә тырышабыз: аннан-моннан акча юнәтеп, йөз меңләгән китап туплап куйдык менә.* Р.Вәлиев. *[Мостафа] Кафедра артына басып, лекцияләр итеп туплап куйган язмаларын ачты һәм: – Бүген безнең тема... – дип, сузыбрак сүз башлаган иде, ишектән Сабира күренде.* Ф.Яхин

**Туплап тору** Даими һәм регуляр рәвештә туплау; һәрдаим туплау; әле, хәзер туплау. *Кем белә синең ни кылганыңны, кайтыр кияең, акча алыр умырып, рәхәт яшәрсез, син дә монда акча туплап торырсың, алар сине буш итми бит.* Р.Батулла. *Менә шушылар халыкны бергә туплап торган да.* Р.Вәлиев

**Туплый бару** Әзлекле рәвештә туплау. *Ничә көннәр бөтенесе пышын-пышын килә, күзгә күренмәгән сайлау алды афәте Биектау кешеләрен бер йодрыкка туплый бара.* Ф.Садриев. *Алар көн саен осталыкларын үстерә, тәҗрибә туплый баралар.* Р.Батулла

**Туплый башлау** Тупларга керешү. *Ул хәзер идарәдә көч туплый башлады, чөнки барысыннан иртә тора, эшкә булдыклы.* Х.Камалов. *Бүгеннән башлап үзебез аралашып яши торган бөекләрнең шәхси әйберләрен туплый башларга вакыт.* З.Мәхмүди

**ТУПЛА́У** II *и. к.* **туплавык**. *Күңел тапталып беткән туплау түгел, ә суган кебек яшел уҗым тели!* М.Әмир. *Тегеләрнең аяк тавышлары тынып калды, немецлар туплау өстенә текәлделәр.* Х.Камалов

**ТУПЛЫ** I *с.* Туплар (II) куелган, туплар белән коралланган. *Бер туплы урыс гаскәре авылга көтү китү белән килеп керде.* З.Зәйнуллин. *Чириковның унбиш-унсигез туплы корабы моңардан күпкә калыша иде.* И.Хуҗин

**ТУПЛЫ** II *с.* **1.** Туп (I) белән уйнала торган

**2.** *и. мәгъ.* Шундый уен. *Кечкенә чакта малайлар белән төрле уеннар уйный торган идек: туплы да, капчыклы да, сугышлы да...* Х.Туфан. *Ул язгы судан калган таш кебек йомры, итләч йодрыкларын йомарлап, киң халат итәкләрен, җиңнәрен җилфердәтеп Һади өстенә очып-очып куна: малай, туплы уйнаганда, ялгыш аларның тәрәзәләрен ваткан икән.* А.Гыйләҗев

**ТУПЛЫК** *и.* 1) *диал. к.* **туплавык**. *Җәй башының матур бер көнендә Галиәкбәр абзыйның сары сыеры, су буенда туплыкта яткан җирдән кинәт кенә сикереп торды да, борынын тәүфикъсыз җыерып җил иснәде дә --- җанфәрманга чапты китте.* Ә.Баян. *Ат җигәргә дип йөгән тотып туплыкка*

*керсәм, теге айгыр тотты да ямады маңгайга!* Х.Ибраһим

2) Юлчы, гаскәр һ.б.ш.ларның ялга туктаган урыны, стан, табор. *Атлар тагып килгән кибиткаларда дистәләгән Рим легионеры качып килгән дә, төн караңгылыгыннан файдаланып, туплыктан кырый якларга китеп яшеренгәннәр.* Р.Сәгъди

**ТУПЛЫ́ ХОККЕЙ** *и. спорт* Боз өстендә кечкенә туп белән уйнала торган командалы кышкы спорт уены; *руссчасы*: **хоккей с мячом**. *Туплы хоккей Европада бенди дип атала.* Р.Шакиров. *Бу – туплы хоккейны алга таба Олимпиада ярышлары программасына кертүгә бер адым булырга мөмкин.* Шәһри Казан

**ТУПРАК** *и. диал., иск. к.* **туфрак**. *Мәдрәсәнең тышкы яктан өелеп куелган тупрак нигезе өстенә озын сакаллы вә гаять һавалы, тәкәббер карт кәҗәләр вә яшь-яшь дәртле кәҗә тәкәләре җыелып кояшта кызынып ятарга башладылар.* Ф.Кәрими. *Аяк астыңда тупрак булыйм.* Г.Исхакый. *Безнең тупракның андый үзенчәлеге юк, мөгаен...* Р.Зәйдулла

**ТУПРАКЧЫ** *и. тар.* XX йөз башында территориаль автономия яклы иҗтимагый-сәяси агым тарафдары. *Шулай булгач, безгә бүген дәүләтчеләргә һәм милләтчеләргә, рәсәйчеләргә һәм татарстанчыларга, татарчыларга һәм төркичеләргә, тупракчыларга һәм мәдәничеләргә бүленергә түгел, ә бөтен Рәсәй җирендә урыс белән бер дәрәҗәдә хуҗа булып, бербөтен һәм бүленмәс төрки-татар милләтен торгызырга кирәк.* И.Хуҗин. *Ләкин тупракчыларның билфигыль (чынлыкта) идарәләре татар большевиклары кулында булганга, алар милли саботажны дәвам иттерделәр вә бергәләшмәделәр.* Х.Миңнегулов

**ТУПСА** *и.* 1) Ишек-тәрәзә ишеләрнең ике өлешен ачылып-ябылып, җыелып-язылып йөрерлек итеп яңакка беркетә торган җайланма. *Менә бу тәрәзәнең бер капкачының тупсасын рәтләп куярга кирәк.* К.Тинчурин. *Уңайлы итеп ясалган киң урындыклар юкка чыккан, җырлап ачыла торган ишек тә бер тупсасында асылынып тора.* Р.Галиуллин

2) Бусага. *Аларның каршысына чыккан кеше, тупса буенда озаклап тотмыйча, артыгын сораштырып тормастан, түргә чакырды.* Ф.Яхин. *Ишек тупсасына утырып, елый-елый, әнисен көткәндә, юеш ыштаны белән бозга ябышып та калгалаган.* Т.Нәҗмиев

3) *диал.* Ишек бавы, ишек тоткасы. *Ишек Йосыф яклы булып чыкты, тиз генә ябылырга теләмәде, тупсага чат ябышып, ыңгыраша-ыңгыраша, исерек марҗа белән тарткалаша башлады.* Г.Гыйльманов

4) *сир.* Ашлык сабагының буынланып торган урыны // Ашлык бөртеге урнашкан оя. *Башаклар тупсаларыннан атылып чыгарга торган күксел эре бөртекләр белән тулганнар.* Г.Галиев

5) *диал.* Колак (мәс., чиләктә). *Тәзкирә, чиләк тупсаларын сайрата-сайрата, капкадан кереп китте.* А.Расих

6) *күч.* Авыл, шәһәр һ.б.ш. башлана торган җир, урын, чик. *Михаил янә Урда тупсасына барып егылды.* М.Әмирханов. *Тора-бара камалыш авыл тупсаларына килеп җитеп тарая.* А.Хәлим

◊ **Тупса акчасы** *этн.* Туй барышында кияү тарафыннан кыз бүлмәсенең ишеген ачучыга бирелә торган акча; ишек бавы. *Кияү егетләре тупса акчасын кызганмый бирделәр.* Г.Гали. **Тупсага утыру** Игеннең сабагы буынлану (гадәттә, орлыклана башлаган вакытта). *Ашлыкның серкәсе вә чәчәге коелып тупсага утыргач та, орлык туя башлыйдыр.* К.Насыйри. *Ә инде игеннәр буйга сикереп, сабан бодайлары тупсага утырганда, арышлар баш кысып серкә очырганда, Рәхимҗан үз аяклары белән туган авылына кайтып төште.* М.Хәсәнов. **Тупса(ны) төшерү** Бик еш килү; күп килеп йөдәтеп бетерү. *Унике хатынны яучылыкка яллыйм, ишегезнең тупсаларын төшергәнче яучы булып йөрерләр.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ТУПСАЛАНУ** *ф.* Игеннең сабагы буынлану, тупсага утыру. *Бодай тупсаланганда дөньяга килдең син, дия иде әби.* Сөембикә

**Тупсалана башлау** Тупсаланырга тотыну

**Тупсаланып җитү** Тәмам тупсалану, тупсага утыру. *Бодай тупсаланып җиткән*

**Тупсаланып килү** Әкренләп, азазлап тупсалану. *Арыш тупсаланып килә*

**ТУПСАЛЫ** *с.* 1) Тупса (*1 мәгъ.*) белән беркетелә торган, тупса ярдәмендә каптырып яки беркетеп куела торган; буынлы. *Хатын-кызлар ул вакытта тоташ һәм тупсалы беләзекне ешрак кигәннәр.* Мәйдан. *Шәһәр хакимияте тарафыннан 190 тәбәнәк тупсалы автобус сатып алынды.* Казан утлары

2) Тупсасы булган, бусагалы. *Хәмит шул җиз тупсалы, җиз келәле нәни тимер сандыкны төшләрендә күреп саташа.* М.Хәсәнов

**ТУ́П-ТУП 1.** *иярт.* Берәр нәрсә бернечә мәртәбә бер-бер артлы төшкәндә яки еш-еш атлаганда, йөргәндә чыга торган саңгырау тавышны белдерә. *Ә бу тавышлар тагын да ешрак кабатлана башлады: туп-туп, туп-туп.* И.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Туп-туп атлап килә көмеш тояк тулпар атым.* М.Хәбибуллин. *Каршыма килеп җиткәч, биегәнгә охшатып, атасыннан калган кирза итеген туптуп басып, селкенеп, бөтерелеп тә алды.* Ф.Баттал

**ТУП-ТУ́П ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Өченче катта, минем фатирым өстендә матур гаилә булып яшәүче Илсөя белән Газизнең балаларының туп-туп итеп чапкан аяк тавышлары минем җаныма куаныч кына бирә.* Татарстан яшьләре

**ТУПЧУ** *ф.* 1) Тукыманың тишелгән, ертылган урынын җеп белән ешеш һәм кат-кат әйләндереп ямау, тегү. *Әни белән бергәләшеп тупчыган оекларны киеп йөри идем.* М.Галәү // Каткат чәнчеп тегү. *Һавадан төшкән туп кына, Аягы-кулы юк кына, Алтын белән тупчыган, Көмеш белән типчегән.* Табышмак. *Анысы инде тәндәге күк кан тамырлары турында: «Бөти-бөти бөтенгән, Бөтиләрен типчегән, Күк җеп белән тупчыган».* Ф.Урманчеев

2) Бау очын сүтелмәслек итеп ирегә үрү яки үрем арасына очларын яшереп үрү. *Бауны тупчу*

3) Укмаштыру. *Төймәне элек тире, йон чүпрәктән тупчып тегеп ясаганнар.* Н.Исәнбәт

4) Аннан-моннан гына сылау, ямау. *Тишекне тупчу. Ертыкны тупчу*

5) Берәр нәрсәне тоташтыру, ялгау. *Тупчып та булмый инде хәзер аны, ташласаң да ярый.* Р.Вәлиева

**Тупчый башлау** Тупчырга керешү

**Тупчып алу** Тиз генә тупчу. *Күлмәк итәген тупчып алу*

**Тупчып кую** Алдан яки тиз арада тупчыган хәлгә китерү. *Тишек оекбашны тупчып кую*

**Тупчып тору** Әле, хәзер тупчу; даими тупчу

**ТУПЧЫ** *и.* Артиллериядә хезмәт итүче кеше; артиллерист. *Тупчы батареялар корал ягыннан да, кием-салым ягыннан да бик өтелгән.* Х.Камалов. *Әткәй сугышта тупчы булган, җае чыга калса, безгә сугышта күргәннәрен сөйләп, хәтерен яңартып ала иде, шуңа күрә артиллерия, туп дигәндә, бераз чамасын белеп сөйләшәбез.* Ф.Сафин

**ТУПЧЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **тупчу**. *Тупчылган кыек якалы җиләннәр [кидек].* З.Бәшири

**ТУПЧЫН** *и. диал.* Кат-кат төреп, чорнап ясалган чүпрәк яки киез туп. *Андый тупчын белән урамда атышып уйнавы бик күңелле була торган иде...* М.Галәү

**ТУПЫЙ** *с.* **1.** Җәенке, ямьшәйгән; очлаеп тормаган. *Әһә-ә, бу тупый танау да кайткан икән!* М.Хәсәнов. *Тупый бүрек*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тирәсенә мех тотылган түгәрәк сай бүрек. *Тупыйны кадим заманда башка киярләр иде. Бүректән кечерәктер. Кырпуы бик тар иде.* К.Насыйри

2) *диал.* Бәйләгән баш киеме, башлык. *Мондый эсседә кем башына тупый киеп йөрсен инде.* Казан утлары

3) *диал.* Элек хатын-кызлар кигән тәңкәле баш киеме. *Ялтыравык тәңкәле тупый*

**ТУПЫЙК** *с.* Очлы түгел, җәенке; ямьшәйгән. *Ниндиләре генә юк аларда: үрдәккә охшаган тупыйк борынлысы, чыпчык сыман кыска канатлылары дисеңме, акчарлак сыман сылулары, аккош кебек озын муенлылары дисеңме!..* Р.Вәлиев. *Алагаем олы башлы, тупыйк гәүдәле, гадәттән тыш кыска аяклы бу ир кеше атлап түгел, ә тәгәрәп килә иде сыман.* М.Галиев

**ТУПЫЙКЛАНУ** *ф. к.* **тумпаклану**

**ТУПЫЙКЛЫК** *и.* Тупыйк булу. – *Тупыйклык баш киеменә генә килешә ул, – дип көлде Әхмәт.* Г.Ахунов

**ТУПЫЛ** *и. рус* Таллар семьялыгыннан төз биек кәүсәле, ялтыравык киң яфраклы агач; тирәк; *русчасы*: **тополь**. *Юан кәүсәле, киң ябалдашлы тупыл астында, кар көртендә нинди зур кара тап анда?* М.Маликова. *Шушы тупыл түбәндәге агачлыкта яшәп яткан бер дивана карттан күчкән аңа бу нигез.* Г.Гыйльманов

**ТУПЫЛДАТУ** *ф. сөйл.* Туп-туп иттереп сугу, чабаклау, бәрү яки басу. *Аңа икенчесе җыр белән җавап бирде: «Ак киндерләр шома була, Тупылдатып тукмасаң».* Ф.Латыйфи. *Бик алҗыган, бик әрнегән чакларында ул аларның барлыгыннан, үзенең аларга кирәк булуыннан көч, юаныч ала; аларның саусәламәт булуларына сөенеп бетә алмый; кечкенәләрен тупылдатып сөеп туя алмый иде.* Д.Булатова

**Тупылдата башлау** Тупылдатырга тотыну

**Тупылдата бирү** Бернигә дә карамый тупылдату. *Аның эше беткән, тубын тупылдата бирә.* Казан утлары

**Тупылдатып кую** Аз гына, кыска вакыт аралыгында тупылдату

**Тупылдатып тору** Даими тупылдату; сөйләү моментында тупылдату. *Аяклары белән һаман тупылдатып тора, әйткәнне дә аңламый бит ул.* И.Нуруллин

**ТУПЫЛДА́У** *ф.* 1) Туп-туп итеп бәрелү, туп-туп килү, сугылу, таптану, тыпырдау. *Ә җеннәр җимеш кортларыдай тупылдап коелып тора, коелып тора.* З.Мурсиев. *Сирәгәйгән тамчыларның үләнгә салмак кына шыбырдап, калай түбәгә тупылдап тамуын тыңлап, урман буендагы бакча өендә утырам.* Өмет

2) *күч. к.* **тупырдау 1.** (*3 мәгъ.*). *Менә ул тупылдап үсәр, әтисенә ияреп печәнгә барыр, борчак чабарга...* Ф.Яхин. *Тупылдап үсеп кенә килгәндә, нибары 3 яшь 7 айлык чагында кинәт чирләп, инвалидлык алды.* Өмет

**Тупылдап кую** Бер тапкыр тупылдау; кыска вакыт аралыгында тупылдау

**Тупылдап тору** Һәрвакыт тупылдау, хәзерге моментта тупылдау. *Теремек, матур малайны иркәләп үстереп ятканда, Сәрия тупылдап торган кыз алып кайтты.* Ф.Дәүләтгәрәева. *Иң мөһиме: тупылдап торган ике малай үстерәләр.* Г.Гыйльманов

**Тупылдый башлау** Тупылдарга керешү. *Август җиттеме, аларның бакчасында алмалар тупылдый башлый.* Р.Вәлиева

**ТУПЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тупылдау** (*1 мәгъ.*). *Өлгерүе җиткән кып-кызыл алмалар, шуны гына көткәндәй, дәррәү тупылдашып җиргә коела.* Д.Булатова

2) Берсе артыннан берсе дөньяга килү; сау-сәламәт, таза булу. *Дөньялары матур, тупылдашып кызлары үсеп килә.* Кызыл таң

**ТУПЫЛДЫК** *с. диал.* Сау-сәламәт, таза

**ТУПЫРДАТУ** *ф. сөйл.* 1) Тупыр-тупыр иттереп бер-бер артлы бәрү, басу, кою һ.б.ш. эшләр башкару; тыпырдату. *Усал ата каз сыман ысылдап, тәпитәгәрмәчләрен тупырдатып туктаган поезд станциядә озак тормады, пассажирларын төшерде дә кузгала да башлады.* Ф.Абдуллин. *Ат та тынгысызлана башлады: басып торган җирендә аякларын тупырдатып өстенә сарылган карны кагып алды.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Үзе алыштырган фигыльдән аңлашылган эш-хәлнең интенсив рәвештә башкарылуын белдерә. *Син бигрәк тиз тегәсең. Тупырдатасың гына.* Сөембикә

3) Бер-бер артлы җибәрү, эшләү һ.б.ш. *Маһирәң сиңа тупырдатып малай табып куандырыр дип әйтә алмыйм.* Г.Галиева. *Инде дә килеп шул торналар, кыр казлары килгәнне күргәч, алардан күзеңне алмыйча гына иелеп, юлдан салам алсаң һәм шул саламны утырган каз оясына куйсаң көт тә тор: ун-унике йомырка өстендә утырган ана каз бөтен йомыркаларыннан да тупырдатып бәпкә чыгарыр.* М.Мәһдиев

**Тупырдата башлау** Тупырдатырга керешү. *Ул, кызның касыгына төртә-*

*төртә, кылый күзе белән егетләргә таба ымлап каш сикертә, аякларын өстәл арасына бәреп тупырдата башлаган иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ат, баскан җирендә түзә алмыйча, аякларын тупырдата башлады.* Г.Гыйльманов

**Тупырдатып тору** Һәрвакыт тупырдату, даими тупырдату

**ТУПЫРДА́У** *ф.* **1.** 1) Тупыр-тупыр иткән тавыш чыгару. *Шушы вакыйгадан соң «кыштырдыклар», пешкән алмалар агачны селкеткәндә җиргә тупырдап коелган кебек, тоткарлыксыз ява торган булып китте.* Д.Гаделшин. *Музей капкасы каршында ярминкә гөрләде, бизәлгән, кыңгыраулы атлар, тупырдап, бала-чаганы утыртырга көтеп торды.* Безнең гәҗит

2) Тупыр-тупыр иткән тавыш чыгарып басу, сикерү, хәрәкәт итү. *Идәндә бала тупырдап йөргәнне күрергә телим.* Х.Камалов. *Баш буталып китте. Димәк, икәү... Киләчәктә җирдә тупырдап атлап китәчәк ике Нуриев...* М.Маликова

3) *күч.* Берсе артыннан берсе килү, чыгу, дөньяга килү, сау-сәламәт булу. *Алты малай, биш кыз тупырдап, берсен берсе карап, туганлыкның кадерен белеп үсәләр.* Сөембикә

**2.** 1) *рәв. мәгъ. күч.* **тупырдап**. Таза, тыгыз булып, түгәрәкләнеп, кабарып. *[Солтан] Фатыйманың тупырдап торган тулы күкрәкләренә тагын бер күз атты.* А.Расих. *Синең ул яктан, энекәш, сөбханалла, беләкләрең тупырдап тора, җилкәләрең дә киң, икешәр капчык куеп ташырлык.* И.Хәйруллин

2) Сау-сәламәт, таза булып. *Ике улыбыз тупырдап үсеп киләләр.* Ф.Сафин. *Ике яшькә кадәр тупырдап үскән, йөгереп йөргән сабыйга ямьле май көннәренең берсендә әллә ни була: грипп белән авырый, ай буе тән температурасы төшми.* Казан утлары

**ТУПЫРДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тупырдау**. *Тояклар ешрак тупырдашырга тотындылар.* Ф.Хөсни. *Көз көне тупырдашып алма коелган вакытның рәхәтлеге сөйләп кенә аңлата торганмы соң?* Р.Вәлиева

2) Бик күп һәм сау-таза булу. *Тигез гаиләдә тупырдашып үсәләр алар.* Г.Мөхәммәтшин. *Алар бер телемне җидегә бүлеп, бер тустаганнан җидәү чишмә суын эчеп, тупырдашып җидәү үстеләр.* Ватаным Татарстан

**Тупырдаша башлау** Тупырдашырга тотыну

**Тупырдашып тору** Сөйләү моментында тупырдашу; гел, һәрвакыт тупырдашу. *Кайчандыр яшь тайлар кебек тупырдашып торган кызлар инде сигезенче дистәне тутырып килә.* Т.Биктимирова

**ТУПЫРСЫК** *с. диал.* Йомры, нык, юан. *[Ул төшендә] тупырсык тәпиле, баш тиресе касмакланган, йомшак авызлы бер малай имезә.* М.Мәһдиев. *Елмаерга торган тупырсык иренле сирень чәчәгедәй Зөмәрә төшеп калды.* Х.Камалов

**ТУПЫ́Р-ТУПЫР** *иярт.* 1) Берәр каты нәрсә җиргә төшкәндә, коелганда чыккан тавышны белдерә. *Ул кагылып киткән ботаклардан җиргә тупыр-тупыр өлгергән алма коелып бара.* Р.Мөхәммәдиев

2) Берьюлы күп кеше яки хайван йөгергәндә чыккан тавышны; көчле аяк тавышларын белдерә. *Тик бераздан гына кайдадыр шәһәр үзәгендә тынлы оркестрның дәртле генә уйнаган тавышын ишеттек тә Большая Казанская буйлап шул якка таба бер төркем атлы солдатларның тупыр-тупыр чаптырып узганнарын күреп калдык.* Ә.Еники. *Малайның куанычы эченә сыймый, иркен җир булса, тупыр-тупыр биеп киткән булыр иде.* А.Тимергалин

**ТУПЫ́Р-ТУПЫР ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Тупыр-тупыр итеп сикергән бу матур кызга карап елмаясы гына килә.* Р.Вәлиева

**ТУПЫ́Р-ТУПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **тупыр-тупыр итү**. *Тупыр-тупыр килеп тояклар биешә иде анда.* Р.Мөхәммәдиев

**ТУПЫРЧЫК** *и. диал. к.* **тубырчык**

◊ **Тупырчык кебек** Сәламәт, таза, тере. *Иренең фаҗигале үлеменнән соң тораташтай катып калган, үз эченә бикләнгән, кулы эшкә бармаган, күзеннән яшь кипмәгән мәлдә, аңа бердәнбере – унбер яшьлек тупырчык кебек баласы – Илдары килеп сыена: «Әни, елама, син ялгыз түгел».* Татарстан яшьләре. *Тупырчык кебек тере, кара күзле икенче сыйныф укучысы Әлфис Гыйззәтуллин да, карашларыннан балалык самимилеге бөркелеп торган Чулпан Галәветдинова белән Алсинә Таһирова да Тукай абыйларына багышлап шигырьләр язганнар икән бит.* Дуслык

**ТУР** I *и. бор. к.* **тургач**. *Ир әйләнеп кулга төшәр, кош әйләнеп турга төшәр.* Мәкаль

**ТУР** II *и. фр.* 1) Вальс биегәндә, бүлмәне яки залны бер тапкыр әйләнеп чыгу; вальста бер әйләнеш. *Вальс туры*

2) Берничә этаптан торган чараның бер баскычы, аерым этабы. *Беренче турда җиңелгәннән соң, ул башка җирдән сайланып үтте.* М.Галиев. *Беренче тур сораулары буенча көч сынашу башланып китте, һәм ул бик киеренке барды.* Т.Нәҗмиев

3) Шахмат турнирында һәр катнашучының берәр генә партия уйнап чыгуы; шахмат турнирының бер өлеше. *Шахмат ярышларын яратса да, бер турны карагач, кайтып китәргә туры килде.* И.Нуруллин. *Беренче турда А.Галләмова җиңде.* Мәгърифәт

**ТУР** III *и.* 1) Берничә гасыр элек яшәгән борынгы кыргый үгез төре. *Ул вакытта күсәк яки таш белән коралланган ялгыз кеше бизон, тур, зубр кебек киекләрне җиңә алмаган, күмәк ау корырга кирәк булган.* Р.Әхмәтьянов. *Мөгезле эре терлекнең төп борынгы нәселе кыргый үгез – тур булган. Кыргый тур XVII гасырда кырып бетерелгән.* Биология

2) Куышмөгезлеләр семьялыгыннан Кавказ тауларында яши торган кыргый кәҗә тәкәсе. *Кавказ тауларында бик җитез тау кәҗәсен (тур) очратырга мөмкин.* Хайваннар дөньясы

**ТУР** IV *и. фр.* Берәр кая оештырыла торган, гадәттә ял, ашау-эчү, экскурсия һ.б.ш.ларны үз эченә алган сәяхәт. *Иң арзан тур 75 мең сум тора.* Н.Алан. *Соң бу тур белән өч мең кеше барасы идек бит, Илдусның мәрхәмәте аркасында 263 кеше ярык тагарак янында утырып калырбызмы?* Ә.Галимҗанова

**ТУРА** I *и.* 1) Эремчек, йомырка, каймак салып ясалган камырдан бик вак күмәч рәвешендә пешереп, сары

май эченә салып катырылган ашамлык. *Әбием бик тәмле итеп тура пешерергә өйрәтте.* А.Галиева

2) Эремчеккә шикәр комы салып, кызарганчы кайнатып ясалган ашамлык; корт. *Әлү каклары, киптергән җимешләр, мәтрүшкәле чәй, катык, күкәй, орлыклы төш, тура... Сыйлары санап бетергесез.* Р.Батулла

**ТУРА** II *и. лат.* Башня рәвешендә эшләнгән шахмат фигурасы; ладья. *Яңа уенда да дүрт йөрештә тура белән ферзьне ашатты.* Г.Ибраһимов. *Һәрбер шахмат фигуралары комплектына шаһ, вәзир, ике тура, ике фил, ике ат һәм сигез пешка кирә.* Ватаным Татарстан

**ТУРАГЫЧ** *и.* **1.** Яшел масса, печән һ.б.ш. нәрсәләрне турый, ваклый торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Турагычтан чыккан печәнне шунда ук ташып торалар.* Р.Вәлиев. *Тамыразыклар өчен электр белән эшли торган турагыч ясап, Лида апасының кул эшен киметкән ул.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Вак кисәкләргә турый торган. *Алар ашыга, алар тырыша, үлән турагыч машина сиптергән яшел массаны таратып өлгерергә кирәк.* Р.Батулла. *Турагыч машиналарның унбише чит илдән кайтартылган икән.* Ватаным Татарстан

**ТУРАЙТКЫЧ** *и. махс.* Алмаш электр тогын даими токка әверелдерә торган җайланма. *Ярымүткәргечле турайткыч*

**ТУРАЙТУ** *ф.* 1) Бөгелгән, сыгылган, кәкрәйгән һ.б. нәрсәләрне туры, төз итү. *Ләкин ул кунычны турайттың ни дә, кайтардың ни.* К.Миңлебаев. *Иелә-бөгелә бәрәңге бакчасын казып азапланган Әхмәтша карт, ике-өч көрәк балчык әйләндереп каплаган саен ах-ух килеп билен турайта да, көрәгенә таянып, бераз хәл ала.* Ф.Имамов

2) *физ.* Алмаш токны даими токка әверелдерү. *Ярымүткәргечле турайткычның каршылыгы аңа тоташтырылган алмаш ток көчәнеше юнәлешенә (полярлыгына) карап үзгәрә: әнә шул үзлеге аркасында ул алмаш токны турайта ала.* Физика

**Турайта бару** Бер-бер артлы һәрберсен турайту; бөгелгән саен турайту

**Турайта башлау** Турайтырга тотыну

**Турайта бирү** Бернигә карамый турайту. *Мәрҗәм, җиргә тартыла башлаган аркасын турайта биребрәк, ул күрсәткән якка карады.* М.Кәбиров

**Турайта тору** Әле, хәзер турайту эшен башкару. – *Син бу иске кадакларны турайта тор әле, балта алып килəм хәзер, – дип, өенә таба йөгерде Сабир.* Р.Вәлиев

**Турайта төшү** Тагын бераз турайту; бераз гына турайту. *Әле бакча якка, әле ишегалдына таба карангалап алгач, күкрәген тагы да киерә, муенын турайта төшеп хәрәкәтсез калды.* Р.Мөхәммәдиев. *Ерактагы таллар, көне буе кояш кызуында сәлперәешеп утырганнан соң, сыннарын турайта төшкән кебек күренәләр, алар инде хәзер яфраклары белән салкынча дымны эчәләр.* Т.Нурмөхәммәтов

**Турайтып алу** Тиз арада турайту. *Инде соңгы мәлдә ниндидер кодрәтле көч машинаны турайтып алды.* Р.Фәизов

**Турайтып бетерү** Барысын да турайту; турайтуны төгәлләү. *Минә шуның [плойка] белән чәчләрен кыздыра-кыздыра бөдрәләтә дә... аннары тарак белән тарап турайтып бетерә, һәм ул бөдрәләрдән берни дә калмый!* Р.Сабыр

**Турайтып карау** Тураямы, юкмы икәнлеген тикшерү. *Шулай да сүтеп алып турайтып карарга исәп, урынында килеш кенә булмый...* А.Тимергалин

**Турайтып кую** Алдан ук турайту; турайган хәлгә китерү. *Сәмигулланың йөзен матурладылар, күзләрен төрттеләр, гәүдәсе кыйшаеп барган кебек иде, аныңсын да матур итеп турайтып куйдылар.* Д.Бүләков. *Янындагы ир-ат, күзләрен юлдан аермый гына, бер кулы белән рульне тоткан хәлдә, кызның утыргычын җайлап, турайтып куйды.* Х.Ширмән

**Турайтып тору** Гел турайту; сөйләү моментында турайту. *Мин килгәндә, сеңлем көзге алдында чәчләрен турайтып тора иде.* Р.Вәлиева

**Турайтып чыгу** Һәрберсен турайту. *Баганаларны турайтып чыгу*

**ТУРАК** I *и. бот. к.* **турак уты**

**ТУРАК** II *и. диал.* 1) Аяк, тәпи, кечкенә тояк

2) *а.х.* Бал кортлары җыеп ташый торган чәчәк тузаны; кәрәз ипие

**ТУРАКЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **тураклау**. *Мендәрләр, матраслар пычак белән тураклананып, идән, өстәл каз мамыгы, матрас мамыгы белән тулган.* З.Зәйнуллин. *Ягъни ул егерме бер яшендә дөм сукыр булып, эче-башы туракланган хәлдә, бала булдырырга сәләтсез бер гарип булып калган.* Ф.Бәйрәмова

**Туракланып бетү** Тәмам тураклану; бик нык тураклану. *Әгәр немецлар бер җирдә дә безнең һөҗүмне туктата алмасалар, һәр фронтта аларны чорнап алу, кырып бетерү дәвам итсә, гомумән, немецларның безгә каршы фронты туракланып бетсә, немец армиясендә тоташ җимерелү һәм бөтен җирдә дә тәртипсез качу башланмасмы?* Ә.Еники. *Ертылып, туракланып беткән рәсемнең вак-вак кисәкләре идәндә аунап ята.* Г.Сабитов

**ТУРАКЛА́У** *ф. кбт. к.* **турау**. 1) Бербөтен, тоташ нәрсәне вак-вак кисәкләргә бүлү; вак-вак итеп кисү, турау. *Бәлки, әйтмәскә кушылгандыр. Янчык Сәләхи бабайлар шул сиерның түшкәсен тураклап, кар базына салдылар да кыш буе ашап чыктылар.* Р.Батулла. – *Дөрестән дә, элек урман авылдан ерак түгел иде, – дип исенә төшерде картларның берсе. – Тик утызынчы елларда ук аны туракларга тотындылар.* С.Юзеев

2) *күч.* Пычак, кылыч һ.б.ш. кораллар белән чапкалап үтерү. *Шунда карт маршал, кызып китеп: «Мин боларны да кылыч белән чабып, тегеләрне дә тураклап тар-мар иттем!» – дип сөйләгәндә, залдан бер казак сугышчысының тавышы ишетелә: «Семён, син берүзең генә тураклаганда, без кайда булдык соң?»* Ә.Хәсән. *Әйләнеп-әйләнеп килеп бомбаларын ташлагандагы мәхшәр, хәзер күземне чытырдатып йомсам да, һич күз алдыннан китми. Туракланып, кисәкләнеп һавага ыргытылган гәүдәләр, куллар, аяклар, ат гәүдәләре...* Л.Хәмидуллин

3) *күч.* Юк итү, үтерү (дошманны). *Әсирләр кирәкми, тоташ тураклагыз!..* В.Имамов

4) *күч.* Рухи газаплау (*күңел, бәгырь, җан* һ.б.ш. сүзләр белән килгәндә)

**Тураклап ату** Тиз генә тураклау. *Беренче эш итеп зур тәлинкәгә аш салды,*

*аннары йомшак назлы куллары белән супермаркеттан атасы алып кайткан ипине вак-вак кисәкләргә тураклап атты.* Ф.Бәллүр

**Тураклап бару** *к.* **тураклый бару**. *Агач ботакларын тураклап бара*

**Тураклап бетерү** Барысын да тураклау; бик күп тураклау; тулысынча тураклау. *Шулай кая барса да яраган, фашистларны җиңеп кайткан фронтовик җиффәрә, хирурглар пычак белән тураклап бетергән эченең кай төшедер чәнчүенә дә карамый, көне шундый!* Р.Газиз. *Театрда әдәби бүлекнең мөмкинлекләрен чикләп, үзе белгәнчә, үзе теләгәнчә ваклап, тураклап бетерә торган кешеләр бар иде.* Ю.Сафиуллин

**Тураклап ташлау** *к.* **тураклап ату**. *Шуннан соң теге исереп йоклап яткан егетне кискәләп, тураклап ташлыйлар.* Әкият. *Ире Локман исә киндер сугу станын тураклап ташлый, җеп йомгакларын утка ата.* Ф.Яруллин. *Сәлҗүк җайдакларына югалып калган, зур табышка өметләнгән әмир атлыларын тураклап ташлау әллә ни кыенлык тудырмагандыр, мөгаен.* Г.Гарифуллин

**Тураклап чыгу** Баштан ахыргача барысын да тураклау. *Ул берәм-берәм барлык хатларны тураклап чыкты.* Казан утлары

**Тураклый бару** Бер-бер артлы тураклау; шунда ук, шул ук вакытта тураклау. *Аларны Морат Сираев «Дружба» пычкысы белән кисеп аударып, тураклый барды, ә ир-атлар машина, трактор әрҗәсенә ташып тордылар.* Якты юл

**Тураклый башлау** Туракларга керешү. *Болгарлар мангытларны әүвәл сөңгеләр һәм гөрзиләр белән урталайга ярды, аннан кылычлары белән тураклый башладылар.* В.Имамов. *Якын араны күз ачып йомганчы сикереп үттеләр дә урыс сугышчыларын тураклый башладылар.* И.Хуҗин

**Тураклый бирү** Бернигә дә карамыйча тураклау. *Кыз, бернигә дә карамый, егетенең фотосын тураклый бирде.* Сөембикә

**ТУРА́К УТЫ** *и. бот.* Укроп. *Кешеләр үләннең орлыгыннан зур зыян күрәләр, чөнки түндербашның орлыклары һәм яшел бәбәкләре турак утыныкына (укроп) бик охшаган.* Агулы үсемлекләр

**ТУРАЛМА** *с.* **1.** Турала торган, туралган, туралырга тиешле. *Туралма печән*

**2.** *и. мәгъ.* Туралган, вакланган масса. *Кипкән туралма*

**ТУРАЛЫ** *с. иск.* Кулга өйрәтелгән; баудагы (ау кошлары тур.). *Туралы кошның баласы – Тумагы күзгә төште лә!* Дастан

**ТУРАМ** *и.* Туралган кисәк, туралган нәрсәнең өлеше. *Сарсымбай акрын, сабыр сайлап, кулына биш турам майлы ит алды да: – Куйчым, кил бире, – диде.* Г.Ибраһимов. *Һәр тәлинкәгә бер турам тавык итеп салып, ашны табынга чыгаралар.* Сөембикә

**ТУРАМА** *и. а.х.* Вак итеп туралган салам. *Былтыргы турама бетеп кенә килә әле, озакка җитте.* Р.Вәлиева

**ТУРАНЧЫ** *и.* Туранчылык тарафдары. *Аларның тикшерүләренең нәтиҗәсен миңа туранчы бер мажар галиме шулай аңлатты: Идел буендагы халыкларда туран каны 96%, Төркестанда 50–60%, Төркиядә 16% ---.* Х.Миңнегулов

**ТУРАНЧЫЛЫК** *и. тар.* Борынгы Туран туфрагында яшәгән хәзерге төрки, ирани һәм монгол телле халыкларның сәяси берләшүен максат итеп куйган идея агымы. --- *Аларны Буа районында крестьян восстаниесе оештыруда, ОГПУ хезмәткәрләрен коралсызландыруда, яңалифкә каршылык күрсәтүдә, Солтангалиев белән бәйләнештә торуда – туранчылыкта гаепләләр.* Р.Вәлиев

**ТУРАҢГЫ** *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан йомшак үзагачлы агач – тупылның җылы якларның тозлакы җирләрендә үсә торган эссегә чыдам бер төре. *русчасы:* **туранга**. *Карт тураңгы*

**ТУРАТ** *и. сөйл.* Туры ат. *Ә менә чабыш атларын, теге туратыбызны ничек әзерлиләр икән?* Г.Хөсәенов. *Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан, Чорлар буйлап җилгән туратта.* Г.Морат. *Туратларга утырып кайтып килер кебек әле дә.* Т.Галиуллин

**ТУРА́У** *ф.* 1) Бербөтен, тоташ нәрсәне пычак яки башка үткер корал белән кискәләү, ваклау. *Без туганнан туганым Мөнир белән кипкән тәмәке яфракларын, сабакларын вак-вак итеп турый идек.* Т.Миңнуллин. *Тавыкларга кычытканны шундый вак итеп турый Гарәфетдин абый ---.* Р.Газиз

2) Пычкы, балта кебек кораллар белән кисү, чабу. *Күптән инде әрәмәдә курай тавышы ишетелми: тегермән буасы өчен турый торгач, әрәмә юкка чыкты.* Р.Батулла

3) *куч.* Пычак, кылыч кебек кораллар белән чапкалап үтерү. *Әй турый да иде соң дошманны!* Г.Кутуй. *Әй, төкерим лә синең ул телеңә! Иң яхшысы, әйдә, ияреңнән төш тә кылыч сайла. Мин сине ялан буенча куалый-куалый турыйм!* В.Имамов

4) *куч.* Юк итү, үтерү. *Гражданнар сугышы – мөселманны мөселман турау сугышы – басмачларны җиңү, бихисап мөселманнарны кырып-суеп, Урта Азияне, Бохараны яулап алу әле яңа гына тәмамланган.* Р.Батулла

**Турап алу** Тиз генә турау. *Хатыны җитез генә ипи белән казылык турап алды да өстәлгә җимешләрне тезде.* Казан утлары

**Турап ату** Тиз генә барысын да турау. *Менә без, егермеләп егет, аларны туктатырга тырышып караган идек тә, унябызны шул угрылар турап атты.* В.Имамов

**Турап бетерү** Барысын да турау; турауны төгәлләү. *Илһамныкылар ун чакрым арада биш меңгә якын баскын җайдакларын турап бетерделәр.* В.Имамов. *Уртада калганнарны тәмам турап бетерделәр.* Р.Батулла

**Турап кую** Туралган хәлгә китерү. *Каенга карап тора да: «Моны кисеп, турап куйсаң, бер куб метр утын чыгар иде», – ди.* Т.Миңнуллин. *Ул сүзен әйтеп бетергәнче, Сәлимә коштабак белән аш күтәреп чыкты, тоз-борыч тезде, калын итеп ипи турап куйды.* Г.Даутов

**Турап ташлау** Тиз арада турау. *Әмма җирле баскынчылар кальга капкасыннан чыгып китүгә баш күтәрә, калада калган гарнизонны турап ташлыйлар.* М.Хәбибуллин. *Монда бәреп кергән болгарлар бу хәшәрәтләрне шундук турап ташламакчы иде дә,*

*аларның кылыч йөзенә яланкул ябышып, Әбүзәр сыбай тыйды.* В.Имамов

**Турап тору** Сөйләү моментында турау; даими турау. *– Мин аны гомеремдә ашаганым юк, – дип утырган иде дә, аннары Габделбәр үткен пәке белән турап торган түгәрәкләрне үз ягына тәгәрәтә генә башлады.* А.Хәсәнов. *Бөдрә чәчле, озын буйлы Эдуард белән чандыр грузин егете Мамука ит турап тора, тышкы кыяфәтләре белән бербарсенә су тамчыларыдай охшаган кылыч борынлы егетләр Альберт һәм Абрик шашлык пешерә.* З.Хөснияр

**Турап чыгу** Баштан ахыргача турау. *Батыр аларны вак кисәкләргә турап чыкты.* Р.Батулла. *Сәлим солтан калдырып киткән төрек пашасын дарга асканнар, нәүкәрләрен кылыч белән турап чыкканнар, ди.* В.Имамов

**Турый бару** Шунда ук турау. *Мин чистарта барам бәрәңгене, әни турый бара.* Р.Вәлиева

**Турый башлау** Турарга керешү. *Бу читке өлешләрне бетергәч, Юныс карт пычагы белән турый башлады.* Г.Ибраһимов. *Ул арада ир дә, исенә килеп, тозлаган кыяр турый башлады.* Р.Батулла

**Турый бирү** Бернигә карамый турауны дәвам итү. *Һаман турый бирү*

**Турый тору** Алдан ук турарга керешү. *Хуҗа хатын: «Юк, юк, гомер эченә бер килгән кунакларны болай гына җибәрәмме соң, төнгә каршы да юлга чыкмагыз, кунып китәрсез, кая, Казан кумәчләре белән майларымны турый торыйм әле», – дип, аш бүлмәсенә юнәлә.* Н.Гариф

**ТУРАЧ** *и.* Фазан кошлар семьялыгыннан куе әрәмәлекләрдә яши торган тавык зурлыгындагы чуар кыргый кош; *русчасы:* **турач**. *Ата турач*

**ТУРАЧИ** *и. диал.* Дүртенче буын ир яки кыз кардәш. *Турачи белән күрешү*

**ТУРАШ** *и.* Сугыш; кан коеш. *Берәр сәгать канлы тураштан соң, болгарлар позицияләрен, бай обозларын ташлап кача башлаганнар.* А.Хәсәнов. *Бу тураштан алар чак котылды.* Р.Батулла

**ТУРАШУ** *ф. урт. юн. к.* **турау**. *Бөек Биләр тирәсендәрәк иркенләп турашырга ипле урын сайлап, позициягә басканнар.* А.Хәсәнов

**ТУРАЮ** *ф.* Бөгелгән, сыгылган, кәкрәйгән, гомумән төзлеген югалтканнан соң, яңадан туры хәлгә кайту. *Кечерәеп калган гәүдәсе дә турайган кебек хәтта.* И.Гази. *Хәзер менә тураya алмыйча, биленә шәл бәйләп йөри.* З.Мәхмүди

**Тураеп алу** Бераз вакытка гына тураю. *Әнисә, безне күреп, азга гына тураеп алды да чүп утавын дәвам итте.* Р.Вәлиева

**Тураеп бетү** Тулысынча тураю; бөтенләй тураю. *Әле бүген дә бик үк тураеп бетмәгән.* К.Кәримов

**Тураеп җитү** Тәмам тураю

**Тураеп калу** Турайган хәлгә килү. *Минем чәчләрем бала тапкач тураеп калды.* Сөембикә

**Тураеп килү** Тураya башлау, тураю билгеләре сизелү

**Тураеп китү** Кинәт тураю. *Ул кагылуга, күзсезләр – күзле, аяксызлар – аяклы, телсезләр – телле булган, бөкреләр тураеп киткән.* Ф.Яруллин. *Кыеграк утырган студентларның аркалары тураеп киткәндәй булды.* Х.Ширмән

**Тураеп кую** Нәрсәдер тәэсирендә тураю. *Ләүфелмәхфүзәнең күкрәге тураеп куйды.* Ф.Баттал

**Тураya бару** Торган саен ныграк тураю. *Инде бөгелергә өлгергән озын буе тураya барды.* Ф.Яхин

**Тураya башлау** Тураю билгеләре сизелү; тураерга тотыну. *Фәнәвинең тумыштан озын һәм бер якка кәкрерәк муены кыскара һәм тураya башлый.* З.Зәйнуллин. *Чыраен сытып тураya башлауга, башкисәр, кесәсеннән «Макаров» пистолеты чыгарып, аның янтыгына төртте.* З.Мәхмүди

**Тураya бирү** Тураюын дәвам итү. *Һәм, менә, тураya биреп, тамак кыргалап алды да, пинжәк чабуын кайтара төшеп, әз генә калтыравык нечкә тавышы белән сузып җырлап та җибәрде ---.* Ә.Еники

**Тураya төшү** Тагын да бераз тураю. *– Без Надя белән өч еллап гел янәшә булдык, – диде ул, урындык артынарак тураya төшеп.* Х.Камалов. *Эш белән мавыгып, Зыятдин карт та беркавымга бар мәшәкатьләреннән арына, йөзе яктырып китә, гәүдәсе тураya төшә ---.* Р.Вәлиев

**Тураya язу** Чак кына тураймый калу. *Тураya язган хәлдә бердәнбер кулын алга таба сузып, нидер әйтмәкче иде, аңлаешсыз ымлыклар гына чыгара алды.* Ә.Баян

**ТУРБА́ЗА** *и. рус* Туристлар базасы; туристлар туктап, куна, ял итә торган урын, бина. *Анапада ул «Биек яр» дигән турбазада ял итте.* М.Маликова. *Анда турбазалар, ял йортлары салып бетергәннәр.* Ф.Бәйрәмова

**ТУРБИ́НА** *и. лат.* Пар, газ, су энергиясен механик көчкә әйләндерә торган двигатель. *Су гөбердәп аска ага, аста турбина ду килеп әйләнә.* Р.Батулла. *Су басымы хәрәкәткә, кинетик рәвешкә күчеп, зур-зур турбиналарны әйләндерергә тиеш.* Н.Шәрифуллин

**ТУРБИ́НАЛЫ** *с.* Турбинасы булган, турбина куелган. *Хәзергесе вакытта Тоскин группасы тагын да ныграк камилләштерелгән турбиналы мотор ясау белән мәшгуль.* Татарстан яшьләре. *Түбән Чыршылыда, турбиналы насос урнаштыру өчен, бер корылма ясап куйдылар.* Заман сулышы

**ТУРБИ́НАЧЫ** *и.* Турбиналар ясаучы белгеч; турбиналарны эшләтүче. *Тәҗрибәле турбиначы*

**ТУ́РБО-** Кушма сүзләрдә «турбиналы» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *турбодинамо, турбонасос*). *Моңарчы «Сельхозтехника» базаларында ремонтланган турбокомпрессор һәм барлык төр ягулык аппаратларын да үзләре ремонтлый башлыйлар.* Т.Нәҗмиев

**ТУРБОБУР** *и. рус* Тирән скважиналар бораулый торган забой машинасы. *Зәй үзенең ниндидер сиземе белән турбобурга су бирүне туктатып, измә насосын вертлюгка ялгаттырды.* Х.Камалов. *Турбобур каты токымны җай гына тишеп барганда, кинәт токым ишелә һәм инструментны кыса, сыта.* Татар әдипләре

**ТУРБОВИНТЛЫ** *с. авиа.* Винты газ турбинасы ярдәмендә әйләнә торган. *Аэрофлотта дөньяда беренче тапкыр реактив пассажирлар самолёты Ту-104, турбовинтлы Ил-18 оча башлый.* Ватаным Татарстан. *Ул чорда реактив һәм турбовинтлы самолётларны үзләштерү башлана.* Кызыл таң

**ТУРБОВОЗ** *и. рус* Пар яки газ турбинасы ярдәмендә хәрәкәт итә торган локомотив. *Газ турбовозы*

**ТУРБОГЕНЕРА́ТОР** *и. рус* Пар, газ турбинасы ярдәмендә алмаш яки даими ток эшләп чыгара торган электр генераторы. *Азнакайга визиты вакытында ТР Президенты шәһәрнең җылылык челтәрләре предприятиеләрендә булды, турбогенераторлар эше белән кызыксынды.* Ватаным Татарстан. *Азнакайда «Водоканалсервис» җәмгыяте филиалы җылылык челтәре предприятиесендә яңа турбогенератор урнаштырганнар.* Татарстан яшьләре

**ТУРБОРЕАКТИВ** *с. авиа.* Реактив хәрәкәт көче турбина көче белән кушыла торган. *Ул елларда завод беренче турбореактив двигательләр эшләп чыгару белән мәшгуль була.* Казан утлары

**ТУРБОХОД** *и. рус* Пар яки газ турбинасы ярдәмендә хәрәкәт итә торган судно. *«Турбиния» исемле беренче турбоход суга 1896 елда төшерелгән.* Сабантуй

**ТУРБУЛЕНТ** *с. лат. махс.* Зыр-зыр әйләнә торган, өермәле. *Монда өченче оператор махсус детонаторлы пультивант ярдәмендә чималның тыгызлык коэффициентын һәм турбулент магнетикасын тикшерә.* Җ.Юныс. *Бик нык селкетә башлагач, бик нык курыктык, аннары җайланды үзе – самолёт турбулент зонага эләккән булган икән.* Казан утлары

**ТУРБУЛЕНТЛЫК** *и. махс.* Өермәле хәрәкәт, өермәлелек. *Бары тик яшен яки турбулентлык кына очкычның юкка чыгуына сәбәпче булырга мөмкин.* Казан утлары. *Безне әлеге дә баягы шул турбулентлык куркыта.* Сөембикә

**ТУРБЫ** *и.* Кечерәк кенә түгәрәк капчык яки савыт. *Ул чакта инде турбыдагы солы шактый кимегән булган.* Әкият

**ТУРГА** *и. махс.* Кулъязманың матурлап, бизәкләп ясалган беренче хәрефе; *русчасы*: **буквица**. *Турга ясалган мондый китапларны кечкенә чакта әни белән икәү укый идек.* Казан утлары. *Электәкеге әкият китапларына гына карагыз сез: беренче хәрефләре зур-зур итеп язылган (турга) сүзләр «мине укы!» дип үзләренә тартып тора бит!* Ялкын

**ТУРГАЙ** *и.* 1) Тургай кошлар семьялыгыннан күбесенчә кырларда һәм болыннарда яши торган сайрар кош; *русчасы*: **жаворонок**. *Күккә эленеп калган тургайларның кинәнеп сайравын күр син!* Г.Мөхәммәтшин. *Елмая кәккүкле, тургайлы яз, Күк күзләр дә, бәлки, елмаер.* Ә.Ерикәй

2) *иск.* Кош формасында пешерелгән кечкенә күмәч. *Балаларның һәммәсенең дә кулларында камырдан ясалган, яңа гына пешкән берәр тургай бар иде.* Г.Тукай

**ТУРГА́Й БОРЧАГЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан урманлы яктагы иңкүлекләрдә, тугайларда үсә торган, кайрысыман яфраклы үлән яки ярымкуак үсемлек; *русчасы*: **астрагал датский**. *Тургай борчагын таныйсызмы сез, балалар?* Мәгариф

**ТУРГА́Й ҖИТЕНЕ** *и. бот.* Канәферсыманнар семьялыгыннан болыннарда, урман кырыйларында, аланнарда, сирәгрәк чәчүлекләрдә үсә торган ак чәчәкле, озынча яфраклы күпьеллык агулы үлән үсемлек; *русчасы*: **звездчатка злаковидная**. *Тургай җитененең чәчәкләре ак була аның, монысы башка үлән булырга тиеш.* Казан утлары

**ТУРГАЧ** *и. бор.* Ау лачыннарын кундыра торган агач, ту. *Икәүне бер тургачка кундырдың.* Әкият. *Иң элек тургачы белән кара лачын күтәреп керәләр.* Н.Исәнбәт

**ТУРИЗМ** *и. фр.* 1) Дөнья күрү, үз иле яки башка илләрнең төрле өлкәләре белән танышу һәм ял итү өчен, җәяү, велосипедта, чаңгыда һ.б.ш. оештырыла торган сәяхәт

2) *спорт* Организмны физик чыныктыру максаты белән төркемләп походларга йөрүдән гыйбарәт спорт төре. *Спелеология – мәгарәләргә керү белән бәйле спорт туризмы.* Шәһри Казан. *Гер күтәрү, милли көрәш, чаңгы туризмы һәм башка спорт төрләренә катнашырга теләүчеләр саны елдан-ел арта.* Кызыл таң

3) Туристларга хезмәт күрсәтү – ашату, яшәтү, транспортта йөртү һ.б.ш. шөгыльләнгән хуҗалык тармагы. *Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршындагы «Идел» яшьләр үзәге инде менә гасыр башыннан бирле ел саен ил күләмендә яшь язучылар бәйгесе оештыра.* Казан утлары. *Туризмнан алынган керемнәр*

**ТУРИСТ** *и. фр.* Туризм белән шөгыльләнүче кеше. *Анда бары тик кыяга менәр өчен махсус әзерлек үткән спортчылар гына һәм аларны карарга туристлар гына килә икән.* Ф.Яруллин. *Ләкин бу ханым да аларны башка туристлар янына озатып кую белән юкка чыкты.* М.Кәбиров

**ТУРИ́СТИК** *с.* Туризмга бәйләнешле. *Узган якшәмбедә Мәдинә Маликова һәм Әхмәт Рәшитовлар килеп утырды. Японияга туристик путёвка белән барып, унсигез көн йөреп кайтканнар.* Ф.Яруллин. *Туристик сәяхәтләр походлар кыенлыгы белән түгел, әнә шул серләре, көтелмәгән ситуацияләре белән кызыклы да инде.* А.Хәсәнов

**ТУРИСТЛЫК** *и.* 1) Турист булу. *Чит илгә килеп төшүгә туристлык дәрте уянды егетнең, барысын да күрәсе, барысын да беләсе килә башлады.* И.Нуруллин. *Япониядән килгән бу галимнең туристлык хисе шундый көчле булып чыкты: шәһәребездәге барлык музейларга, экскурсияләргә йөрүне әллә кайчан планына язып куйган инде ул.* Сөембикә

2) Туризм. *Беренчедән, халыкны тарихи истәлекләр белән таныштыру, икенчедән, туристлык эшчәнлеген җәелдереп җибәрү өчен дә шартлар туар иде.* М.Галиев. *Әлбәттә, алар хуплавының хикмәте, бер яктан, федераль мирас булып саналган тарихи ядкәрләребезне саклап калу, аларны дөньяга күрсәтү, туристлыкны үстерүдә булса, икенче яктан, Россия кебек күпмилләтле ил җитәкчеләре өчен диннәргә һәм милләтләргә тигез караш идеясен тарату мөмкинлегенең бүген аеруча мөһимлеген аңлау.* Казан утлары

**ТУРКА** I *и. бор. хәрби* Сугышчының тимер баш киеме

**ТУРКА** II *и. иск.* Кытай ефәге. *Сигез дигән – серкә, тугыз дигән – турка, ун дигән – уймак, бозда таймак.* Табышмак. *Кара лачын кау итсәм, Шоңкар сайлап чөярмен; Катифәне хурласам, Турка сайлап киярмен.* Дастан

**ТУРКА** III *с. диал.* Эре бөртекле. *Турка арыш. Турка бодай* // Сатар өчен әзерләнгән яхшы ашлык. *Кытай ефәкләренең иң үтемле төре борынгы төркичә торку, торгу, торка, торга дип аталган (татарча турка – «калын ефәк тукыма» сүзе «туйга барсаң туеп бар, турка туның киеп бар» мәкалендә, шулай ук диалекталь турка «базарлык, сатуга исәпләнгән ашлык» сүзендә чагыла).* Р.Әхмәтьянов

**ТУРЛЫ** *с. диал.* Чигүле. *Музейда безгә әбиләребезнең чигелгән, каелган, савырлы һәм турлы читекләр киеп йөрүе турында сөйләделәр, борынгы заман читекләре мисалында аларның чигелеш үзенчәлекләрен аңлатып бирделәр.* Казан утлары

**ТУРМАЛИН** *и. нем.* **1.** Радиотехникада, оптикада кулланыла һәм кайбер үтәкүренмәле, матур төсле төрләре асылташ булып санала торган кристаллик төзелешле минерал. *1325 рубин һәм турмалин, 559 фирүзә, 16 энҗе, 28 сапфир һәм 36 башка асылташлар белән бизәлгән, кыйммәтле металлардан эшләнгән бу тәхетне финанс яктан, тарихи яктан аеруча, бәяләп тә бетереп булмый.* Татар заманы. *Соңгы елларда фирүзә, лазурит, турмалин, халцедон, сапфир кебек асылташлардан милли стильдәге алкалар һәм йөзекләр ясау белән шөгыльләнә ул.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Шул минералдан ясалган. *Турмалин муенса*

**ТУ́РМАН** I *и. нем. сир.* Дирбия, кирәк-ярак

**ТУ́РМАН** II *и. нем. зоол.* Күгәрчен кошлар семьялыгыннан нәселе ясалма юл белән барлыкка китерелгән токымнан, очкан вакытта мәтәлчек ата ала торган күгәрчен. *Тоныук кызгылт канатлы, ак муенлы турманнар тагын элеккечә, йомшак түшләрен җиргә бәрергә теләгән сыман түбән ыргылып, төшеп җитте дигәндә генә, кинәт канатларын җәеп җибәреп, җиңел гәүдәләрен югарыга чөеп уйнакларга керештеләр.* К.Нәҗми

**ТУРНЕ** *и. фр.* 1) Төрле шәһәрләргә, илләргә һ.б. барып, яңадан башлангыч пунктка кайтара торган маршрут буенча сәяхәт; гомумән сәяхәт. *Бөтен татар шәһәрләрене гизермен, чит мәмләкәтләрдә турне ясармын.* Г.Исхакый. *--- син илләр гизеп, турне ясап кайтмаган.* М.Хәсәнов

2) Артист яки спортсменнарның чит җирләргә (шәһәрләргә, өлкәләргә, илләргә) гастроле. *Без ил буйлап турнега чыгасы идек. Килешүләр төзелгән, концерт заллары, мәдәният йортлары арендага алынган.* Р.Габделхакова. *Бу чорда ул Татарстан һәм Башкортстанның бөтен татар авылларында диярлек концертлар куя, СССРның төп шәһәрләрендә һәм татарлар тупланып яши торган төбәкләрендә чыгышлар ясый, чит илләргә турнега чыга.* Р.Зәйдулла

**ТУРНЕПС** *и. ингл.* 1) Әвернәчәчәкләр семьялыгыннан икееллык үлән үсемлек; мал шалканы. *Дөрес, бу сиңа шикәр чөгендере түгел, ә турнепс – мал азыгы.* З.Мурсиев. *Кишер басуы бетте, ди, турнепс үсми, ди.* Р.Фатыйхов

2) Шул үсемлекнең терлек азыгы итеп үстерелә торган сусыл итләч тамыры. *Малайлар төркеме су буенда очраша, турнепслар инеш суында юыла, пәкеләр белән чистартыла.* Татарстан яшьләре

**ТУРНИК** *и. фр.* Ике терәккә беркетелгән аркылы тимер таяктан гыйбарәт гимнастик снаряд. *Әйтик, солдатка килгән малай турникта бер тапкыр да күтәрелә алмаса, марш-бросок вакытында маңкасын агызып арттан сөйрәлсә, өйрәнүләр чорында миңгерәп торса, аңа китереп бәрүләре бик табигый!* М.Маликова. *Байтак курсташлар биредә дөм бөрешеп калды, кайсы берсе турникта бердән артык тартыла алмый.* Р.Зарипов

**ТУРНИКЕТ** *и. фр.* Кешеләрне берәм-берәм кертү һәм чыгару өчен әйләнмәле әвернә рәвешендә ясалган җайланма, ишек һ.б. *Аның киләсен белеп торган диярсең, проходнойга керүгә, каршыга турникеттан Хәйруллин үзе килеп чыкты.* М.Маликова. *Кайтып киткәндә, шулай ук турникет аша картасы белән уза, бу – укучы кайтып китте дигән сүз.* Д.Сәфәров

**ТУРНИР** *и. нем.* **1.** 1) Урта гасырларда: рыцарьларның хәрби ярышы

2) *спорт* Катнашучыларның һәрберсе үзара бер генә мәртәбә очрашудан гыйбарәт спорт ярышы. *Башта мин аны бик дәрәҗәле шахмат турнирларында катнашучы, үтә хәтәр йөреш алдыннан тирән уй, исәп-хисапка, анализга чумган гроссмейстерга охшаттым, әй.* А.Хәсәнов. *Мәктәптә һәр елны көрәш буенча турнирлар үтә.* Г.Сафиуллина

**2.** *с. мәгъ.* Катнашучыларның һәрберсе үзара бер генә мәртәбә очрашудан гыйбарәт. *Шахмат буенча Казанда үтә торган турнир ярышларында катнашу иде аның хыялы.* Сабантуй

**ТУРСАЕШУ** *ф. урт. юн. к.* **турсаю**. *Я, юлдаш, алай турсаешмыйк әле.* Р.Фәизов

**Турсаешып тору** Турсаешкан хәлдә булу

**ТУРСАЙТУ** *ф.* Үпкәләп, ачуланып, нәрсәдәндер ризасызлык белдереп, авыз, ирен тирәсен кабарту, бүлтәйтү. *Мин ни әйтим, авыз турсайту һәм җилкә сикертүдән башка чарам юк иде бит.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә андыйларга авыз турсайту һич тә килешми.* Ф.Яхин

**Турсайта башлау** Турсайтырга тотыну. *Һәр әйткән сүзгә авыз турсайта башласаң, иренең кабартма булыр.* Р.Вәлиев

**Турсайта төшү** Элеккегедән дә күбрәк турсайту. *– И-и, син бигрәк инде, – диде Люция, иренен турсайта төшеп, – тулай торакның тәрәзәсен сылап йөрер өчен институт бетердемени мин?* Ф.Яруллин

**Турсайтып йөрү** Озак вакыт дәвамында турсайту; гел турсайту. *Шәһәр түгел лә авызны гел турсайтып йөрергә.* Д.Бүләков

**Турсайтып кую** Кинәт, ни сәбәпледер турсайту. *Әби үпкәләгән сабый төсле иренен турсайтып куйды.* Р.Габделхакова

**Турсайтып тору** Әле, сөйләү моментында турсайту. *Үзенең кайда икәнен аңлагач, үпкәләгән кыяфәт белән бераз авызын турсайтып торды да иренеп кенә көлгәндәй итте.* Р.Вәлиев

**ТУРСАЮ** *ф.* 1) Берәр кешегә үпкәләүдән, берәр нәрсә белән ризасызлыктан авыз яки ирен бүлтәю. *Малай ашавыннан туктады, аксыл керфекләре тетрәнеп, иреннәре үпкәләгәндәй*

*турсайды.* М.Маликова. *Иренсез булып та иреннәре турсайган иде.* Ф.Яхин

2) *күч.* Ачулану, үпкәләү. *Иркә бала үпкәли дә күркә кебек кабарына, турсая.* Ш.Галиев. *Аңа каршы, ачуы кабара гына барган Сәҗидәсе турсаеп: «Анасы янында ич...» – дип, үтә төксе җавап бирде.* Г.Галиева. *Мин, турсаеп, әнигә мөлдерәп карыйм.* Д.Булатова

**Турсаеп алу** Аз гына вакыт турсаю. *Ул аз гына турсаеп алды да кабат елмая-көлә башлады.* Татарстан яшьләре

**Турсаеп йөрү** Озак вакыт дәвамында турсаю; гел турсаю. *Турсаеп йөргән вакытларымны елмаеп кына искә алам хәзер.* Р.Вәли

**Турсаеп тору** Хәзерге вакытта турсаю. *Малай турсаеп торуын дәвам итте, беркем дә аны ышандыра алмады.* Ялкын

**Турсая бару** Торган саен күбрәк турсаю. *Йөзләре караңгылана, иреннәре турсая барды туташның.* Р.Вәлиев

**Турсая башлау** Турсаерга керешү. *– Әйдә, бакчага менеп утырыйк, – диде Гөлшаһидә, турсая башлап.* Г.Әпсәләмов

**Турсая бирү** Элеккегедән дә күбрәк турсаю, аның саен турсаю; турсаюын дәвам итү. *– Сиңа шул врач сүзе генә сүз, – диде Рәмзия ханым, турсая биреп, – ә минем хәлемдә кайгың юк синең.* Ә.Еники

**ТУРСАЮЧАН** *с.* Бик тиз үпкәли торган, үпкәчән. *Турсаючан кыз*

**ТУРСЫК** I *с.* 1) Җәенке, кабарынкы, бүлтәйгән; түгәрәк. *Турсык борынлы бер офицер сестраны вагоннан күтәреп төшерде.* А.Таһиров. *Түгәрәк битле, үпкәләгән сыман турсык иренле кыз, өнәмичә генә, күз кырые белән Идрисовка карап алды.* Х.Камалов

2) *күч.* Үпкәчел; артык тиз үпкәләүчән (кеше тур.). *Турсык адәм*

**ТУРСЫК** II *и.* Су, кымыз һ.б.ш. сыеклык салыр өчен күннән тегелгән тар авызлы капчыксыман зур савыт; саба. *Бер турсык суны тәмамән эчеп бетергәч, комда бераз аунады да, сузылып, бер тарафка таба китте ---.* К.Насыйри. *«Корсак» дигәне гамәлдә турсык – мал карыныннан тегелгән капчык, ватылмый да, су да үтми, ялгыш бүселеп кенә китмәсә…* Г.Якупова

**ТУРТА** *и.* 1) Акмайны эреткәндә барлыкка килә торган оеган сөт сыман куе утырма. *Мишәрләр – татар халкының мае да, туртасы да.* В.Ильясов. *Эретеп карасаң, майның яртысы – турта, ягъни кулланырга ярамый торган кушылма.* Ватаным Татарстан

2) Ит пешкәндә шулпага чыга торган, пешеп куерган каннан гыйбарәт аш күбеге. *Ярый инде, кайнап чыккач, ит туртасын ала белмисең икән, хет тозын чамалап сал, дидем…* Р.Батулла. *Әбекәй дә аштан турта таба алмыйча аптыраган иде.* Р.Гаязетдин. *Ашка салган итнең туртасы (күбеге) тизрәк чыксын өчен, тоз салырга кирәк.* Ватаным Татарстан

**ТУРТАЛЫ** *с.* 1) Туртасы (*1 мәгъ.*) алынмаган, туртасыннан арындырылмаган (сары май). *Турталы май*

2) Балавыз матдәсе кушылган, саф түгел (бал тур.). *Беләсез инде, икмәк балы турталы, балавызлы була.* Т.Гыйззәт

**ТУРЫ** I *с.* **1**. 1) Кәкре-бөкре булмаган, бөгелмәгән, төз. --- *«Хатын-кызлар, кәкре аякларын каплар өчен, озын күлмәк тектерә башладылар, ягъни озын күлмәк кигән хатын-кызны күрсәң, бел, аның аяклары бик үк туры түгел», – дигән [фәйләсуф].* Р.Батулла. *Сәгать төрле очраклы кунаклар өчен дип тоткан бер тәрәзәле почмак бүлмәдә эленеп тора һәм күптәннән йөрмәгәнгә охшый, чөнки эленеше үк туры түгел, ул үле бер декорация генә булып калган.* А.Тимергалин

2) Иң кыска, иң якын (юл һ.б. тур.); *киресе:* **әйләнеч, урау**. *Күршеләргә бара торган трактор-комбайннар авыл аша йөрмиләр, авылны читләтеп, басу яктан туры юл белән генә китәләр.* Н.Фәттах. *Баксаң, авыл белән утар арасында туры юл да булган.* Г.Гыйльманов

3) Теге яки бу пунктларны, оешмаларны, кешеләрне турыдан-туры тоташтыра торган (элемтә, юл, газүткәргеч, бәйләнеш һ.б.ш. тур.). *Хәлне туры чыбык буенча Мәскәүгә хәбәр иттеләр.* Г.Ахунов. *Мондый очракларда Чаллы җитәкчеләре белән туры элемтәң булмаса, мәгълүмат дөньясында адәм мәсхәрәсенә каласыңны көт тә тор.* Ж.Дәрзаман

4) *лингв.* Төп, беренчел (сүз мәгънәсе тур.); *киресе*: **күчерелмә**. *Шурочка, аның соравын туры мәгънәсендә аңлап: – Медицина белешмәләребез үзебез белән, – диде.* А.Хәсәнов. *«Шагыйрь» әсәрендә Тукай катлаулы метафораларга, сынландыруларга мөрәҗәгать итми, сүзләрне туры мәгънәсендә куллана, алынмалар да юк.* Т.Галиуллин

5) *лингв.* Сөйләмдә үзгәртелмичә кулланылган (чит кеше сөйләме тур.; *киресе*: **кыек**). *Бәлки, шуңа күрәдер минем беренче хикәяләремдә, бигрәк тә туры сөйләмнәрдә, андый сүзләр шулай кыскартылган шәкелдә языла торганнар иде.* Р.Батулла. *Чөнки әкиятләр, нигездә, җиңел, җайлы укыла (тыңлана) торган гади җөмләләрдән тора, туры сөйләмгә корыла.* М.Вәлиева

6) *мат.* Берсенең артуы (яки кимүе) икенчесенең артуына (яки кимүенә) китерә торган. *Дәресләрдә туры һәм кире пропорциональ бәйлелекнең графикларын төзүгә тиешле игътибар бирәм.* Р.Әхмәтбаева. *Ике зурлыкның берсе берничә тапкыр артканда (кимегәндә), икенчесе шулкадәр тапкыр артса (кимесә), андый ике зурлыкны туры пропорциональ зурлыклар дип атыйлар.* Математика

7) *мат.* Почмакны ясаган яклары арасы 90° ка тигез булган. *– Нигез яссылыкларына перпендикуляр булса, ян кырлары туры, ян кырлары туры почмаклар булса, – диеп, иптәшебез китаптан иҗекләр чүпләргә тотына.* Р.Сәгъди

8) *күч.* Дөрес, гадел. *– Хөкүмәтнең туры хөкеменә тапшырам, – диде карт.* М.Мәһдиев. *Аптырап тормадык, биисе урында балериналарыннан шәбрәк биедек. Судья буласы урында туры хөкемле судья булдык.* Һ.Такташ

9) *күч.* Уендагыны яшермичә, ачыктан-ачык әйтүче; саф күңелле (кеше тур.). *Юкса бит, чыннан да, минем әни дә, синең бабаң да туры кешеләр булып чыкмыйлар.* Т.Гыйззәт. *Элегрәк мин Хәйдәрне саф күңелле, туры кешедер дип уйлый идем.* М.Кәбиров

10) Гадел, намуслы. *Туры кәсептән алай кеше корсак үстерә алмый ул.* Г.Ибраһимов. *Намуслы, гадел, дөрес, туры булу сыйфатларына ия хакимнәр*

*бармы соң ул яки кайчандыр булганнармы, дигән сорау бирергә мөмкиннәр миңа.* Р.Якупов

11) *күч.* Яшермичә, ачыктан-ачык әйтелгән (уй-фикер, сүз тур.). *Исхакыйның һәр сүзе җылы һәм хисле, тере һәм туры, шигырьгә битараф татарны да уйландыра торган тирән кичерешле.* Т.Галиуллин

12) *күч.* Хыянәтсез, ышанычлы, тугры. *Тукта әле, нигә син миңа сугасың, нигә сугасың, ә? Туры хезмәтемнең әҗере шушы булдымы, ә?* Т.Гыйззәт

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Төз, бөгелмичә. *Чырае коточкыч: ап-ак, тәне гомер азык күрмәгән кешенеке сыман искиткеч ябык, гәүдәсен туры тота алмый, бөкрәеп йөри.* Х.Ибраһим

2) Нәкъ каршындагы предметка таба; алга; кыекка түгел. *Басты да укытучысының йөзенә туры карады.* Р.Батулла. *Ә күктәге кояшка туры карарлык түгел, керфекләрем аша гына, күземне ачар-ачмас карыйм.* Г.Якупова. *Баржа, туры барырга теләмәгәндәй, кинәт уңга борыла башлады һәм тиздән агымга аркылы ятты.* С.Сабиров

3) Ике арада булган пунктларга (шәһәр, авыл, өй, каралты һ.б.ш.га) тукталмыйча, кермичә, турыдан-туры. *Көтеп торам, туры өйгә кайт, дип калган идем, ике сәгатьтән әйләнеп тә кайтты.* Л.Ихсанова. *Кияү белән кәләш кенә туй киемнәреннән, калганнары комбинезоннардан, яшь пар загстан туры эш урынына килгән булса кирәк.* М.Маликова

4) Читкә тайпылмыйча, башка бернәрсәгә керешмичә, иң элек; кереш сүзсез, аңлатып торуларсыз гына; турыдан-туры (әйтү, сөйләү тур.). *Моны минем беләсем килде һәм туры гына шуны Хафазадан сорадым.* Ә.Еники. *Ул моны шаяртып әйтмәкче булды сыман, ләкин бу бик туры әйтелде, тупас итеп әйтелде.* Н.Фәттах

5) Ике арада булган нокталарны читләтеп узып, турыдан-туры нәкъ тиешле җиргә. *Узе генә туры барып, туры кайта алмаячагын яхшы аңлаган Тәүфыйк ярдәмгә сеңлесе Равияне алды.* Җ.Дәрзаман. *Мәсәви баба, беркемнең әйтүен көтмәстән, туры кушышка юнәлде.* Н.Фәттах

6) Төзәгән нәрсәгә тидерерлек итеп, төз. *Бу фигыльнең борынгы мөстәкыйль мәгънәсе «ялгышу (шуннан язык – «гөнаһ»), туры тидерә алмау, язлыгу – угың мәрәнең якыныннан үтү, тимәү».* Р.Әхмәтьянов. *Шуңа, дошман якынлашкач, туры наводка белән генә атырга мәҗбүрбез.* В.Нуруллин. *Иң мөһиме шул иде: снарядны күпергә туры атырга булыр, ә минә өскәрәк китәрме ул, әллә барып җитмәсме – бер мәртәбә булса да атып карамыйча белеп булмый.* И.Хуҗин

7) Ике арадагы инстанцияләрне, кешеләрне читләтеп. *Туры президентка керү*

8) Дөресен яшермичә ачыктан-ачык (әйтү, язу тур.). *Ә Шәрәф андый мәсьәләләрдә миннән иртәрәк, яшь көе туры әйтеп, туры яра иде бит, шуның өчен дә ул бик еш «янды», хәзер мин дә «янам».* Н.Нәҗми. *Кыю кешеләрне, туры әйткәннәрне яратам, ләкин үзем, кыюсызланып, әйтер сүземне әйтми калам.* Г.Хөсәенов

9) *күч.* Намус белән, саф күңел белән. *Без тормышка туры карый алабыз. Һәрвакыт якты тойгылар белән, бөек идеяләр белән янабыз.* Ә.Ерикәй // Хыянәтсез рәвештә, ышанычлы, турылыклы булып. *Кешенең кем булуына, кайдан килүенә карамастан, аякка бастыруны максат итеп, биргән антына туры калып эшлиләр шул.* И.Кәримов. *Ә бит кара кайгы китергән хәбәрнамәдә алар турында, социалистик Ватан өчен сугышта биргән антларына туры калып, батырлык һәм каһарманлык күрсәтеп, хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булды, дип язылган.* Т.Кәримов

**3.** *и. мәгъ.* 1) *мат.* Туры сызык. *Әгәр ике турыны өченче туры белән кисстергәндә, эчке аркылы яткан почмаклар тигез булсалар, бу турылар параллель булалар.* Геометрия

2) Тирә; берәр нәрсәнең яки кешенең каршысы, алды. *Чыннан да, кешеләр безнең турыга килеп җитүгә, арадан бер егет аерылып чыгып кычкырып җибәрә ---.* А.Гыйләҗев. *Безнең турыга чүмечле «Беларусь» туктаган.* Д.Булатова

3) Як, юнәлеш, урын. *Монгол, төрки гаскәрләрнең, аларның ханнарының Ерак Көнчыгыштан хәтле тәре күтәреп килмәүләре, Болгар һәм Идел буйларына, Урта һәм Үзәк Азия турыларына җиткәч, --- төркиләргә каршы тоташ дошманлык юлына басканнар икәнлеге килеп чыга.* Б.Рәхимова. *Хәзер минә бик авыр, сагыну-юксыну газаплары йөрәкне бик талаган чакларда, алар баткан турыга барам да сөйләшәм үзләре белән.* М.Хәсәнов

4) *сөйл.* Берәр мәсьәлә, як. *Бу яктан гына кысмады, ул аны башка турылар белән бик кыса һәм имә иде.* М.Гали

5) Очрак, мәртәбә, юл. *Я инде, я, бер турыга гына җиңгәң сүзен дә тыңла.* Казан утлары

6) Вакыт, мизгел, чак. *Караболакка алар кичке якта, көтү кайткан турыда кайтып керделәр.* Ф.Бәйрәмова. *Кояш баткан турыда кайтып керде әтиебез.* Сөембикә

7) Берәр нәрсәнең дөресе, чыны. *Турысын гына әйткәндә, ул мескен егет җылы аш, йомшак түшәк күрмәде.* Т.Гыйззәт. *Турысы гына шул: ул сине алдый! Ул сине алдаган!* Н.Фәттах. *Уку ягына килгәндә, турысын әйтим, мактану кыен иде.* З.Мәхмүди

8) *диал.* Нинди дә булса эш, мәнфәгать, йомыш. *Бая әдәбият кичәсеннән килгән акчаны харам дигәч, мин аларны бик тәкъва кешеләрдер дип белгән идем. Үз турыларына килгәч, тәкъвалык бер якта торып тора икән.* Г.Камал

◊ **Туры әйтергә кирәк** *кер. сүз к.* **дөресен әйтергә кирәк**. *Туры әйтергә кирәк, бүгенге көндә шунсыз булмый.* Р.Вәлиев. **Туры (гына) әйткәндә** *к.* **турысын (гына) әйткәндә** *Туры гына әйткәндә, мин Казанда каласы кеше түгел идем.* Р.Вәлиев. **Туры куллы** Намуслы, хыянәтсез; кеше хакына керми, кеше әйберләренә тими торган. **Туры сүзле** Дөресен ачыктан-ачык, яшермичә әйтә торган кеше турында. *Мондый зирәк акыллы, туры сүзле адәмнәр сарайда бер Мөхәммәдьяр гына түгел, әлбәттә.* М.Әмирханов. **Турысын әйтергә кирәк** *к.* **турысын әйткәндә**. *Һәм, турысын әйтергә кирәк, Аяз Гыйләҗев белән аның гомеренең соңгы берике елында гына, анда да сирәк-мирәк кенә, «син»гә күчәргә җөрьәт иттем*

*бугай.* Р.Хәмид. *Турысын әйтергә кирәк, бу гүзәл кызның мин ямьсезне күрмәве миннән чын егет ясады да куйды.* Н.Шәрифуллин. **Турысын (гына) әйткәндә** *кер. сүз* Әйтелгән-сөйләнелгәннәрнең дөрес, хак, чын булуына басым ясаганда кулланыла. *Турысын гына әйткәндә, мин аңарга кияүгә чыкканда алдын-артын уйлап торырлык хәлдә түгел идем.* Ф.Хөсни. **Туры төтенле** Усал, коры мөгамәләле, бик таләпчән кеше турында. *Әйе, теле тырнаклы шул Мирхәтнең. Үзе дә туры төтенле, принципиаль, хәтта бераз кирерәк сүзле.* Ш.Маннур. **Туры юл** Җәмгыять һәм кешелекнең әхлак кануннарына ярашлы; намуслы, дөрес тормыш итү рәвеше. *Я Аллам, адашканнарга туры юл күрсәт, гөнаһлы бәндәләреңне ярлыка.* Д.Йосыпова. *Санаулы ураза көннәрен тәмам итеп, сезгә туры юл күрсәткәне өчен, Аллаһыны олылагыз, шөкер итегез.* А.Шәймәрдән. **Туры юл белән теге дөньяга җибәрү** *сөйл.* Кеше үтерү. *[Нәгыйм:] Ноктаны туры юл белән теге дөньяга җибәрүче кеше – менә кем!* Ш.Камал

**ТУРЫ** II *с.* **1.** 1) Гәүдәсе гадәттә җирән, кызыл, шулай ук сары яки карадан гайре теләсә нинди төсле, ялы, койрыгы һәм аякларының аскы өлеше кара булган (ат төсе тур.). *Яшь, кырыс туры ат аңардан һаман арты белән чигенеп маташа иде.* Ә.Еники. *Почмакта тугарылган туры алаша арбадан печән чемченә, сарай эченнән дуңгызлар чинаганы, мыркылдаганы ишетелә.* М.Маликова. *Туры ат, караңгылыкта юл табып, юыртып китте.* Д.Бүләков

2) Катлаулы ат төсен белдергәндә: ялы, койрыгы һәм аякларының аскы өлеше кара, гәүдәсе исә сүзнең икенче компоненты белдергән төстә булган (ат төсе тур.). *Туры бурлы булып туган кайбер колыннарның сабыйлык йоны бераздан соң, җир өстенә сибелгән ак чәчәкләр яисә ак йөзгә чыккан матур кара миңнәр кебек, тәңкә-тәңкә булып чуарлана башлый.* Г.Ибраһимов. *Тимершәех абый безгә үзенең елан туры айгыры белән тимерхутын бирде.* Х.Сарьян. *Ат җигәрлек, кара туры айгырны бу буранда каты кул белән алып барырлык кеше юк.* Г.Ахунов. *Кола туры ат колакларын шәмрәйтеп, куркып пошкырып җибәрде һәм сыртыннан шуышып ычкына башлаган авыр гәүдәне өстерәп читкә чабып китте.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Шундый төстәге ат. *Турыны җигү*

**ТУРЫГА** *рәв.* 1) Йөз белән торган юнәлешкә; читкә, як-якка түгел; турыдан-туры кирәк ноктага. *Үзе белән ул бер сакчыны алды һәм ташлы такыр сукмактан турыга Аксай үзәненә таба юнәлде.* Н.Фәттах. *Турыга китсәң, Фукс бакчасына барып чыгасың.* Г.Әпсәләмов

2) Авыш, кыйгачлап яки почмак ясап түгел. *Уңдарак, текә тау аша турыга колхоз юл салды.* З.Зәйнуллин. *Әнә кала өстендә төтен баганалары боз сөңгеләредәй турыга катып калганнар, куып таратучы юк.* М.Әмирханов

**ТУРЫДА** *бәйл. к.* **турында**. *Соңыннан, өйгә кайткач та, бу турыда никадәр сүз булды безнең.* Л.Ихсанова. *Ләкин ана да, кыз да бу турыда телгә алып сөйләшмәделәр.* М.Мәһдиев. *Без әле икебез дә ул турыда төптән уйлый алмыйбыз.* Г.Галиев

**ТУРЫДАН** *рәв.* 1) Кыска юл белән; әйләнеп йөрмичә

2) *күч.* Яшермичә, ачыктан-ачык, кинаяләп, читләтеп тормастан. *Я, турыдан әйт инде, нәрсә сузып торасың.* Аманулла. *Каршына басып, турыдан ярып сорадым: – Ни кирәк сезгә?* Р.Габделхакова

◊ **Турыдан бәрү** 1) Берәр урынга туп-туры юнәлү. *Егет турыдан бәреп клуб каршына килеп чыкты да каты итеп сызгырып җибәрде.* Р.Вәлиев. *Халык турыдан бәреп, юлны кыскартып йөрергә ярата.* Туган як; 2) Уйлаганны, әйтәсе килгәнне яшермичә. *– Озаккамы? – диде Гайфулла, турыдан бәреп.* Ф.Яруллин. *Без турыдан бәрергә яратабыз.* Х.Ибраһим. *Ул дөреслекне турыдан бәреп әйтүдән тайчанмады.* А.Әпсәләмова. **Турыдан суктыру** *к.* **турыдан бәрү**. *Днепр елгасына карап турыдан суктырырга тырышалар.* З.Зәйнуллин. *Америка, Голландиядә халыкларның, шул җөмләдән крестьяннарның да ничек яшәгәнен күреп шаккаткан Сабит әтисенең турыдан суктырган соравына нинди җавап биреп котылырга белмәде.* А.Гыйләҗев. *Егет, аны күрүгә, турыдан суктырды: металл өчен кешеләр һәлак була!* Х.Камалов. **Турыдан яру** *к.* **турыдан бәрү**. *Беляшкина аларның холкы белән артык санлашып тормый, турыдан яра, каршы әйткәнне яратмый, тозлап-борычлап туздырып ташларга да күп сорамый, диләр.* Р.Вәлиев. *Дөреслекне турыдан ярып әйтүе аркасында ул үз гомерендә төрледән-төрле кыенлыклар да кичерде.* Р.Нуруллина. *Исәнме юк, саумы юк, турыдан ярмасынмы теге: «Фаик Газизович?»* Җ.Дәрзаман

**ТУРЫДА́Н-ТУРЫ** *рәв.* **1.** 1) Иң кыска юл белән. *Тоткын иптәшләре никадәр генә турылыклы, батыр йөрәкле булмасын, алар бит илгә турыдан-туры кайтмый.* Г.Әпсәләмов

2) Нәкъ кирәк кешегә, арадашчысыз. *Бүлек мөхәррирләре белән сөйләшеп тормастан, кулъязмасын турыдан-туры редакторга керткән икән ул.* Т.Галиуллин. *Кем ул Гомәрова? Әгәр институттан булса, ник турыдан-туры өйгә язмаган?* М.Маликова

3) Тыгыз, якын мөнәсәбәтләрдә. *«Изге урыннарыбыз», «Кушам ат», «Алдым каләм, яздым сәлам...», «Йөрәк язмалары», «Шәҗәрә», «Вакыт көзгесе» – болар укучыларыбыз белән турыдан-туры бергәләп эшли торган сәхифәләребез.* И.Иксанова

4) Башкарылачак эшкә, әйтеләчәк сүзгә бернинди кереш ясамыйча (керешү, кучү, тотыну һ.б.ш. тур.)

5) *күч.* Ачыктан-ачык; яшермичә, кинаясез (сөйләшү, әңгәмә алып бару тур.). *Бүген Россиядә бер генә халыкка өстенлек бирелгәне турыдан-туры әйтелә.* Т.Миңнуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Арадашчысыз. *Шунысын гына әйтәм: газета укучылары белән атна саен турыдан-туры элемтә оештырылачак.* И.Фәйзрахманов

2) Алдан яздырылмаган, он-лайн бара торган; тамашачыларга шул ук вакытта күренә, ишетелә торган. *Турыдан-туры эфир. Турыдан-туры элемтә*

**3.** *кис. функ.* Бары тик, нәкъ. *Монысы инде турыдан-туры сезнең гаеп.* Р.Ишморат

**ТУРЫ́КАНАТЛЫЛАР** *и. зоол.* Ике пар тупас алканатлары булган бөҗәкләр отряды; *русчасы*: **прямокрылые**. *Турыканатлылар отрядына керүче кайбер бөҗәкләр авыл хуҗалыгына бик зур зыян сала.* Биология. *Турыканатлылар канатларын бер-беренә ышкып тавыш чыгаралар.* Мәгариф

**ТУРЫ́ КИЛҮ** *ф.* 1) Очрау, тап булу, юлыгу, эләгү. *Шул хәлдәнме, әллә инстинкт шулай иттердеме: аның аягы кинәт чокырга туры килеп каймалгандай булды, һәм ул җиргә барып төште.* Х.Камалов. *Үч иткән сыман, мин чабасы урында гел ботак туры килеп тора.* Н.Әхмәдиев

2) Очрашу, бер-берсенә юлыгу, юллары бер тирәгә төшү, кисешү. *Фронтка барганда, сортировочныйда бергә туры килеп танышып киткәннәр иде.* Х.Камал

3) Берәр эш-хәл очраклы рәвештә билгеле бер вакытка төшү, берәр вакытка карау. *Азан вакытына туры килеп, гомерендә кеше түгел, чебенне дә рәнҗетмәгән авыл карчыгының теләге чыннан да кабул булдымы, әллә, кызлар өчен кайгырып, йөрәгенең бер кылы өзелдеме, утырган җирендә оеп кына китте әби.* М.Әхмәтшина

4) Билгеле бер урынга эләгү; билгеле бер урында булу. *Каратаяк дип кенә әйтү аз булыр монда, аждаһа оясына туры килдем мин.* Н.Кәримова. --- *клубта аның урыны һәрвакыт минем янга туры килә.* Ф.Яруллин

5) *мат.* Бер-берен каплау, бер-беренә тәңгәл килү (фигуралар, сызыклар тур.)

6) Теге яки бу яклары, сыйфатлары белән бердәй булу, тәңгәл килү. *Бөтен яктан шушы рольгә туры килгәнемне күреп, Празат абый бирердә дә кимсетергә ирек бирмәде.* Р.Сәгъди. *Хәлбуки фраза, гомумән алганда, эчтәлеге белән дә, формасы белән дә оригиналга туры килә.* Р.Юсупов

7) Берәр эшкә яраклы, ихтыяҗга җавап бирерлек булу. – *Шуның хәтле зур базарда сиңа туры килерлек күлмәк юктыр инде,* – диде ул, *ачуын тыя алмыйча.* Казан утлары

8) Муафикъ килү, муафикъ булу. *Аек акылга туры килмәгән, аңа каршы эшләнә торган бик күп нәрсәләр бар.* Х.Камалов

9) Килеп чыгу, булу, туу (җай, форсат һ.б. тур.). *Хәдис, тәмле калҗаны лачкылдатып чәйнәгәндәй, зур канәгатьлек белән тиз генә әйтеп ташлады: «Әйтмәм дигән идем, үзең әйттерәсең, абый, җае туры килгәндә, хәмердән үзең дә баш тартмыйсың икән».* А.Вергазов

10) Берәр төрле булып чыгу. *Кыш бик салкын туры килде ул елны, әллә кайларга барып йөреп булмады.* Р.Вәлиев. – *Ничектер шулай туры килгән,* – *дип сөйләде миңа әни,* – *кайтканда тагын очраткан Искәндәр абыең теге кызны.* В.Нуруллин

11) *з.-сыз.* Билгеле бер сәбәп, хәл аркасында ни дә булса эшләргә мәҗбүр булу. *Хәзер, кызу эш вакытында, кем белә, бәлки, атналар, айлар буена бригададан чыкмый ятарга туры килер.* Н.Фәттах. *Хәзер исә бөтенесен үз өстемә алырга, хәсрәтне эчемә йотарга туры килде.* М.Маликова

12) Өлешкә чыгу, тию, эләгү, насыйп булу. *Балның быел да бик яхшысы туры килде әле безгә.* Р.Вәлиева

13) Берәр кешегә яки кешеләр төркеменә билгеле бер мөнәсәбәттә булу. *Ул миңа туганнан туган туры килә*

14) Берәр нәрсәнең күләме, саны, башкасы белән чагыштырып исәпләгәндә, билгеле бер нисбәттә, процентта булу. *Сөрүлек җирләренең бер гектарына 46 килограмм минераль ашлама туры килә.* Н.Алан. *Болгар Ислам академиясендә укырга теләүчеләр арасында бер урынга өч кеше туры килә.* Мәдәни җомга

**ТУРЫ́ КИТЕРҮ** *ф.* 1) Берәр кешене билгеле бер урында эзләп табу, күрү, очрату. *Бу көнне Газинур колхозның бөтен хуҗалыгын йөреп, карап чыкты, Һашимны, Сәлимне күрде, Газзән янына да кергән иде, өйдә туры китерә алмады.* Г.Әпсәләмов

2) Уңайлы вакыт, җай сайлау, билгеләү, табу турында. *Мин җайлы чакны туры китерергә чамалап барам.* Ф.Яруллин

3) Берәр эшне икенче эш вакытына чамалап, билгеләп башкару. *Армиядән кайтып, бер ел узгач, отпусканы бергә туры китереп алабыз һәм кайда да булса очрашабыз.* Р.Вәлиев

4) Берәр әйбергә яраклаштыру, охшату. *Суны, сыраны яки чәйне дә үзенең тән температурасына туры китереп кенә эчә иде.* Ф.Баттал

5) Бер әйберне икенче әйбернең нәкъ өстенә, эченә төшерү, элэктерү, тидерү, кертү һ.б. *Томшыкларына туры китереп, төбәп ыргыткан кебек хис итте үзен Мәрьям.* Н.Каштанов. *Күрешкәндә учларны учка туры китерә алмыйча интектек.* Г.Гыйльманов

6) Яраштыру; тиеш булганча, кабул ителгәнчә; гореф-гадәт буенча үткәрү, эшләү, башкару һ.б. *Син – безнең бердәнбер кызыбыз, йоласына туры китереп, кешечә урнаштырасыбыз килә.* М.Әмирханов

**ТУРЫЛАНУ** *ф.* 1) Туры, төз хәлгә килү; тураю. *Хатынның бераз кәефе килгәндәй булды, кашлары турыланды, хуплап, ияк каккалап торды.* Х.Камалов. *Юзеев манараның һәр елны авыша баруы турындагы мәгълүматны халык язмышына, киләчәгенә китереп бәйли: «Манарабыз турыланыр, Милләт үзе аумасмы?»* Т.Галиуллин

2) Дөрес юнәлеш алу. *Кыйбласы турыланган халыкның инде биле дә турая башлады.* Татар заманы

**Турылана башлау** Турылану билгеләре күренү. *«Монда йөрүнең файдасы булды, баланың күзләре турылана башлады», – дип, сөенече белән уртаклашты әти кеше.* Ватаным Татарстан

**Турылана төшү** Бераз турылану. *Шулвакыт теге кешенең гәүдәсе турылана төшә, һәм ул: «Мә, мине күтәреп ал да олактыр инде!» – дигән шикелле, үзе дә сизмәстән, Җәләйнең кочагына барып кера.* Н.Яһүдин. *Тау авышлыгына салынган урамыгыз без таптаудан бераз турылана да төшмәде микән?* Ә.Моталлапов

**Турыланып бетү** Тәмам турылану

**ТУРЫЛАП** *рәв.* 1) Берәр җанлы-җансыз нәрсәнең каршысында, турысында, янында. *Сезнең өегез турылап җыела да инде безнең сарыклар.* И.Нуруллин. *Минә шушы авыл турылап Ык ярында бер тау куышы бар.* Г.Галиев

2) Туры итеп карап, текәлеп. *Солдатларның кулсызы моңарга бик турылап [карап], башыннан аягына кадәр күздән үткәрде.* Ш.Мөхәммәдев

3) Нәрсәгә таба булса да туры юнәлеш алып. *Кыз күлгә турылап борылды да кулларын акрын гына, бик салмак кына, торналар канаты кебек итеп җилпегәндәй итте.* М.Хуҗин. *Элеватордан симәнә ташучылар салган сукмакка шуннан турылап кына төшү иде исәбе.* Г.Әдһәм

4) Туры иттереп; туры итеп куеп; турайтып; төз итеп. *Егет, уң кулын рульдән ычкындырмыйча, сул кулына көзгене алды һәм аны җайлап, турылап, үзе каршысында тотып бара башлады.* Н.Фәттах. *Хисмәтнең күңеле сизенеп алды, һәм, җәһәт кенә машинасын турылап, асфальт юлга борырга өлгерде.* Ф.Яхин

5) Нәрсәгә дә булса туры юнәлешне билгеләп. *Аннан кыйбланы турылап, намазга басты.* Ф.Бәйрәмова

6) Туры китереп. *Икеләнүгә сәбәпче, ихтимал, егетемнең туганнары Сабан туена дип турылап Сарманга килеп төшүләре һәм --- Сабан туен да көтмәенчә, ашык-пошык китеп барулары булгандыр.* К.Миңлебаев

**ТУРЫЛАТУ** *ф.* Турайту, төзәйтү. *Арып-талып, ызан турылатып өйгә кайтып килүче әби белән оныкның күзе күрше Хәтирәләр бакчасына төште.* Э.Якупова. *Эш бетсә, бер өем тутыккан кадак турылатып утырам – бетмәс-төкәнмәс даң-доң.* Шәһри Казан

◊ **Турылатып әйткәндә** *диал. к.* **турысын әйткәндә**. *Турылатып әйткәндә, эшләр яр якасында.* Ф. Сәйфи-Казанлы

**ТУРЫЛА́У** *ф.* 1) Туры, төз, тигез хәлгә китерү; турайту, тигезләү. *Кыекны гына турылау авыр ул.* Ф.Яруллин. *– Галстугыгыз кыйшайган, турылап куегыз, абый, – дип шаяртты аларның берсе.* Р.Вәлиев

2) Бер предметка икенчесен яраклаштыру, тигезләү, туры китерү. *Далада утырган тәртип буенча, вагоннарны тиешле урынга борып, турылап куйдылар, чатырлар өчен урын җайладылар, тракторларны, тагылма инвентарьны шулай ук тиешенчә сафсаф итеп тезделәр.* Н.Фәттах. *Имеш, китабыңны өстәл почмагына турылап куймадың, болай гына салдың, укучылар шуннан күреп китапка саксыз мөнәсәбәткә өйрәнәләр.* М.Мәһдиев

3) Нәрсәне дә булса теге яки бу юнәлешкә бору, билгеле бер якка (урынга) юнәлтү, карату; (коралны) берәр нәрсәгә төзәү. *Кыз күлгә турылап борылды да кулларын, акрын гына, бик салмак кына, торналар канаты кебек итеп җилпегәндәй итте.* М.Хуҗин. *Телсез үзенең биноклен тавыш килгән якка турылады.* З.Мәхмүди

4) *диал.* Дөресләү, дөрес хәлгә кую. *[Сәгать] нишләп дөрес булмасын, радио буенча турылыйм бит.* Н.Фәттах

5) Билгеле бер вакытка, моментка, әйбергә, кешегә һ.б.ш.ларга туры китерү. *Икеләнүгә сәбәпче, ихтимал, егетемнең туганнары Сабан туена дип турылап Сарманга килеп төшүләре һәм, хатыннар гайбәтен рәхәтләнеп тыңлаганнан соң, --- Сабан туен да көтмәенчә, ашык-пошык китеп барулары булгандыр.* К.Миңлебаев. *Шушы белдерүенә турылап сөйләгән беренче кыйссасы болайрак.* Р.Зарипов

**Турылап бетерү** Барысын да турылау. *--- кәкре-бөкре дөньяны Айсинә генә мамыклап, җайлап, йомшартып, турылап бетерә аламы соң?!* Н.Көбәш

**Турылап кую** Тиз арада яки алдан туры хәлгә китерү. *Малайлар юл уртасындагы стрелканы күчереп куялар да, кияү икенче юлга чыгып китә, малайлар стрелканы җәһәт кенә тагын турылап куялар да, кияү артыннан килүче кыз беренче урынга чыга.* Р.Батулла. *Алай көчең булгач, капка баганасын турылап куяр идең хет.* Ф.Баттал

**Турылап тору** Һәрдаим турылау. *Кияү егетләре ярдәмләшеп, читкә тәгәрәгән борчакларны кабат-кабат турылап торалар.* Ватаным Татарстан. *Ышанып тапшырыйк яшьләргә дилбегәне, тартсыннар, турылап тору – бездән, корылтайдан, өммәттән.* Шәһри Казан

**Турылый бару** Вакыт үткән саен тагын да турылау. *--- мөселман кинофестивале елдан-ел камилләшә, ә иң мөһиме, кыйбласын турылый бара.* Мәдәни җомга

**Турылый башлау** Турыларга керешү. *Аннары гел син эштән кайткан вакытка турылый башладым.* И.Гази

**Турылый төшү** Тагын бераз турылау, турырак итү. *Аякларын турылый төште*

**ТУРЫЛЫК** *и.* 1) Туры, төз булу сыйфаты; кәкре, бөкре булмау. *--- Тупылларда – турылык; Ул турылык әллә ничә Горурлыкка торырлык.* Р.Миңнуллин. *Гомумән, Илдусның картиналарында кискенлек, сызыкларның турылыгы, почмакларның катылыгы күзгә ташлана иде.* М.Маликова

2) Дөреслек, чынлык. *Изгелек, турылык эзләп йөри, имеш!* Н.Фәттах. *Монда да мәңгелек турылык тапмадым дип үкенеп, ул үзенең кем икәнен ачып бирә.* М.Мәһдиев

3) Гаделлек. *Кылыч белән түгел, турылык һәм чынлык белән көчле кешеләр.* М.Җәлил. *Ул кемне генә уйнаса да, аның геройларына һәрвакыт сабыйлык, самимилек, турылык хас.* А.Габәши

4) Барысын да ачыктан-ачык, яшермичә сөйли алу сыйфаты; туры сүзлелек, эчкерсезлек. *Элеккеге хәрбилек, кыйты почмакларны әйләнеп үтә белмәү, турылык аның карьерасына нокта куйды.* Т.Галиуллин. *--- заманында, моннан ничәмә еллар элек, Зөлфия Бәйрәшева, үзенә хас турылык һәм кыюлык белән, «халыкның әхлагын һәм әдәбен торгызу өчен, мәдрәсәләр кирәк» дип язган иде бит.* А.Тимергалин

5) Намуслылык, хыянәтсезлек; кемгә яки нәрсәгә дә булса тугрылык, чын күңелдән бирелгәнлек. *Я, минем турылык белән хезмәт итүемә ышандыгызмы инде?* К.Тинчурин. *Бүген, беренче июнь иртәсендә, сугыш беткән беренче тыныч җәйдә, үз йортының өйалдында кинәт кенә Асафның хәтеренә әнә шул табигать баласы – үзе теләп фронтка киткән һәм күпме-күпме ир-ат арасында үз намусын туган җирне саклаган кебек үҗәтлек, турылык белән саклаган гүзәл кыз Зәһинә төште.* М.Мәһдиев

**ТУРЫЛЫКЛЫ** *с.* Намуслы, хыянәтсез; берәр кешегә яки эшкә чын

күңелдән бирелгән. *Синең хакта турылыклы кешеләрдән яхшы сүзләр ишеттем.* М.Акъегет. *Гөлүсә турылыклы дустының шулай итәчәгенә һич кенә дә шикләнми иде.* М.Хәсәнов

**ТУРЫЛЫКЛЫЛЫК** *и.* Турылыклы булу сыйфаты. *Ни кызганыч, дөньяның яктылыгы булган мөэмин оятын югалтты, аңарда вафа – сүздә тору, турылыклылык юк.* Ш.Абилов. *Тәкъдир әманәте диг ән нәрсә, аңа турылыклылык дигән нәрсә бетте.* М.Хәсәнов

**ТУРЫЛЫКСЫЗ** *с.* Берәр кешегә, идеягә, эшкә хыянәт итүче (кеше тур.). *Кешеләр арасында моның кебек турылыксыз һич булмас.* Татар әдипләре

**ТУРЫЛЫКСЫЗЛЫК** *и.* Турылыксыз, хыянәтчел булу; гаделсезлек. *Турылыксызлык беркемне дә бизәми*

**ТУРЫ МӘРӘ** *и.* Аркылы таякчык өстендә яткан икенче таякчыкның башына бәреп, атылып төшә торган вакытында, аңа сугарга тырышудан гыйбарәт уен; чүрәкә. *Балалар туры мәрә уйный*

**ТУРЫ МӘРӘТӘ** *и. к.* **туры мәрә**

**ТУРЫНДА** *бәйл.* Кем яки нәрсә хакында, билгеле темага. *Көннәрнең берендә, җаен туры китереп, тегесе төзелеш турында сөйләгәндә, Тәүфыйк аны, сиздерми генә, матур иттереп язып та алды.* Җ.Дәрзаман. *– Безгә күгәрчен турында инша язарга кушты лар, – диде беркөн Гөлгенә, әнисенең өйдә булуына шатланып.* Р.Габделхакова // Теге яки бу мәсьәләдә, очракта; турысында. *Аннары профессор, Гөлшәһидә белән Мансурны үз кабинетына алып кереп, Гөлшәһидәнең булачак диссертациясе темасы турында сүз башлады.* Г.Әпсәләмов. *Бирегә сүз кемнедер кабатлау, әзер өлгеләргә иярү турында бармый.* Т.Галиуллин

**ТУРЫНДАГЫ** *бәйл.* Берәр кеше яки берәр нәрсә хакында булган, билгеле темага багышланган. *Тынлык урнашкач, аның башына тагы шул язылачак хат турындагы уй килде.* А.Расих. *Аннары мехдворга керделәр, механизаторларның тракторлар искелеге, запчастьлар кытлыгы турындагы зарын тыңладылар.* М.Маликова

**ТУРЫПОЧМАК** *и. сөйл. к.* **турыпочмаклык**. *Шунда ук алдан билгеләп куелган угланнар келәмгә турыпочмак рәвешендәге тәгаймәтне китереп җәйделәр.* М.Әмирханов. *Ринат абый кесәсеннән турыпочмак булып типтигезгә бөкләнгән чип-чиста кульъяулыгын ала.* Идел

**ТУРЫПОЧМАКЛАП** *рәв. мат.* Туры почмак ясап. *Урамны ул турыпочмаклап, яшел светофорга гына чыга торган иде.* М.Маликова. *Мондый урыннар булмаганда, ике юнәлеш тә яхшы күренә торган җирдән, юлны турыпочмаклап кичү мөһим.* Якты юл

**ТУРЫ́ПОЧМАКЛЫ** *с. мат.* Бер почмагы 90 градуска тигез булган. *Ә хәзер син безгә, ягъни бу бүлмәдә утырган иптәшләреңә, турыпочмаклы параллелепипед турында да сөйләп, аңлатып бир әле!* Р.Сәгъди. *Турыпочмаклы өчпочмакның бер катеты гипотенузадан 3 см га кыскарак, ә икенче катеты гипотенузадан 6 см га кыскарак.* Алгебра

**ТУРЫПОЧМАКЛЫК** *и. мат.* Барлык почмаклары да туры булган геометрик фигура. *Турыпочмаклыкның озынлыгын 4 см га киметеп, киңлеген 5 см га арттырсаң, мәйданы турыпочмаклык мәйданыннан 40 см$^2$ га зуррак булган квадрат килеп чыгар.* Алгебра. *Билгеләр – сызыклар, контурлар, төрле төстәге һәм формадагы штрихлар, геометрик билгеләр (түгәрәк, квадрат, турыпочмаклык, өчпочмак), хәрефләр һәм берничә хәрефтән торган аңлатмалар рәвешендә булырга мөмкин.* Башлангыч география курсы

**ТУРЫСЫ** *и.* **1.** Дөресе; бөтен дөресе. *– Турысы шул, ханым, – диде Ямгырчы би, утка ташланырга җыенган кеше сыман. – Бир миңа кызың Аппакны!* Н.Фәттах

**2.** *кер. сүз функ.* Дөресен әйткәндә. *Турысы, ул бу хакта берни дә белми әле.* И.Нуруллин

**ТУРЫ́ СЫЗЫК** *и. мат.* Ике нокта арасындагы иң кыска ераклык. *Әгәр дә туры сызык (бирегә кисемтә күздә тотыла) ничек тә булса киселгән булса, ул вакытта барлык турыдагы квадрат кисемтәләрдәге квадратлар белән бергә кисемтәләр арасында урнашкан турыпочмаклыкны ике тапкыр алганга тигез.* Алгебра

**ТУРЫ́СЫЗЫКЛЫ** *с.* Туры сызык буйлап сузылган, туры сызык буенча бара торган. *Механика фәне җисемнең тигезләнеш шартларын һәм турысызыклы тигез хәрәкәтен дә өйрәнә.* Фән һәм тел. *Автобус турысызыклы тигез хәрәкәт итә.* Әйләнә-тирәбездә физика

**ТУРЫСЫНДА** *бәйл. к.* **турында**. *Вәт менә безнең кешеләргә ашау турысында үзеңне тотарга кемнәрдән өйрәнергә!* М.Мәһдиев. *Үзем сиңа шул малай турысында кайчаннан сөйләп утырам, ә үземнең шуны чыгып апкерергә уема килмәгән.* В.Нуруллин

**ТУРЫСЫНДАГЫ** *бәйл. к.* **турындагы**. *Чөнки моның белән үзенең «бүләк алыш, бүләк биреш кебек нечкә» эшләрдән дә хәбәрсез түгеллеге күренү өстенә, хатын-кыз әйбере ала белү турысындагы уңганлыгы да исбат ителә иде.* Ш.Камал. *Мәскәү турысындагы карарыбызны иртәгә ишетерсез.* И.Хуҗин

**ТУРЫТЫН** *рәв. диал.* Берәр кеше яки берәр нәрсә турысыннан, яныннан, тирәсеннән. *Әйе, Фазыл эше начар, әгәр гади Әсмалар йөргәнә бу Сәфәрләр турытын юл салсалар!* С.Баттал

**ТУРЫ́ ЭЧӘК** *и. анат.* Кешедә һәм югары төзелешле хайваннарда юан эчәкнең соңгы өлеше: эчәкнең матдәләр алмашы калдыкларыннан бушану өчен кыска көпшә рәвешле очы. *Операция вакытында туры эчәккә әз генә пычак очы тиеп тишелеп калган.* Х.Камалов. *Юан эчәк белән нечкә эчәк арасында чик юк, туры эчәк клоакага ачыла.* Биология

**ТУСРЫЙ** *с. сөйл.* Күпереп, мыймылдап торган; симез (бит, йөз тур.). *Түр яктан Луиза тусрый битле имчәк баласын күтәреп чыкты.* А.Расих

**ТУСТАГАН** *и.* 1) Чүмеч; саплаяк. *Ул, башы сызлаганга чыдый алмыйча, ялантәпи килеш кенә өйалдына чыгып, андагы кисмәктән тустаган белән су алып эчте.* З.Мәхмүди. *Тап-такыр булып калган канлы башына бер тустаган су сипкәч, Әхмәди, ниһаять, аңына килде.* Аманулла

2) Чынаяк чокыры, чынаяк йомрысы, пыяла. *Әни көчләп бер тустаган чәй эчерде, «артык сүз ычкындырма» дип кисәтеп, мине мәктәпкә озатты.* А.Тимергалин. *Ни... хөрмәтлем, миңа*

*токмач, тавык, бер тустаган сөтле чәй...* Р.Батулла

3) Стакан яки зур рюмка. *Һәркөнне төшкә кайткач, ул әтәч белән шөгыльләнә: тустаган төбенә аракы сала, аракыга борыч куша да сыйны идән уртасына куеп, әтәчне чыгара.* Ә.Баян. *Идән уртасындагы камыш өстәлдә ике тустаган, шешәләр, капкач та йотарлык итеп вак-вак туралган ит кисәкләре, тавык бавыры, аерым тәлинкәдә симез сарык койрыгы күренде.* А.Гыйләҗев

4) Касәдән зуррак, гадәттә агачтан ясалган түгәрәк савыт, кечерәк тирән табак. *Сабит соң кайтты, ашамады, бер тустаган катык сорап алды, эчәргә ашыкмады, уртлап куйгач, кунаклардан бигрәк Сөмбеләсенә карады.* А.Гыйләҗев. *Ә ашарга тустаган төбендә нибарысы берничә бәрәңге кала.* Ф.Яруллин

5) Зур, гадәттә агач табак; шава. *Кинәт теге тустаган тоткан малай белән тартмалы кеше бәрелештеләр.* Р.Батулла

◊ **Тустаган күзле** Зур түгәрәк күзле. **Тустаганы мөлдерәмә тулу** Сабырлыгы төкәнү, түземлелеге бетү. *Күрәм, тустаганың чыннан да мөлдерәмә тулган синең, Иштуган. Әтиең синең урынында булса, болай гына шауламас иде әле.* Г.Әпсәләмов. *Тустаганы мөлдерәмә тулган Динә монысын чамалый иде.* Ф.Җамалетдинова

**ТУСТАК** *и. диал. к.* **тустаган**. *Зур казан белән аш пешерергә һәм зур-зур тустак ашны ике-өч тиен көмешкә сатарга керештем.* М.Гафури. *Аның хуш үлән исе килеп тора торган шурпасын тустак берлән бәрәңге кабып кына чөмерделәр.* Г.Исхакый. *Без берәр тустак чәй эчтек.* С.Кудаш

**ТУСТЫГАН** *и. диал. к.* **тустаган**. *– Я, нигә авызыңа су каптың? – дип көлә-көлә, иренә тустыган тоттырды.* М.Әмирханов

**ТУСТЫК** *и. диал. к.* **тустак**. *Кәҗә, кәҗә, мә, кәҗә, Әрәмәгә бар, кәҗә. Савар идем утырып, Тустыгымны тотырып.* Такмак

**ТУСТЫРУ** *ф.* Баланы кулга тотып тәрәт иттерү, сидерү; аяк тоту, тәпи тоту. *Мин инде, әледән-әле арбаларыннан сикереп төшеп, чак кына алга китеп баласын тустырып, соңыннан терт-терт итеп обоз артыннан йөгергән Мәрьямбикәгә игътибар иткән идем.* М.Хәсәнов

**ТУТ** I *и.* **1**. 1) Гадәттә кояштан һәм авырлы вакытта бит яки муен тирәсендә барлыкка килә торган кара яки саргылт тап. *Бичара, бөтен авыл егетләренең күз явын алган Хәернисаның битенә тут төшә башлаган иде инде.* М.Мәһдиев. *Кул-аяк бармаклары кәкрәеп бетте, битләрен кара-сары тут, әллә ниткән миңнәр басты.* Д.Булатова

2) Үсемлектә була торган кызгылт сары яки саргылт төстәге гөмбә авыруы; күгәрек; тутык гөмбәсе; гомумән күзәнәкләр үлүдән үсемлек сабакларында яки яфракларында барлыкка килгән коңгырт сары тап. *Үләннәргә сары тут йөгергән.* Н.Әхмәдиев

3) *к.* **тутык 1.** (*1 мәгъ.*). *Эшләгән тимер ялт итәр, эшләмәгәнен тут басар.* Әйтем. *Дагасы юк, инде тут та төшкән.* И.Диндаров. *Рәхмәт, балакаем, алтынга тут кунмас, яхшылык онытылмас, ди торган иде әти мәрхүм, бу яхшылыгыңны беркайчан да онытмам.* С.Поварисов

4) *күч.* Күңелдә ниндидер хәлдән, вакыйгадан соң калган эз, тәэсир. *Чыныкканга тут йокмый.* Г.Хөсәенов. *Кешеләргә әйтер сүзе аның күңелендә озак кайный, хис тимерлегендә тут, көектән арынып-тазарынып, әгәр шулай әйтергә яраса, чыныгып-чүкелеп чыга.* Р.Идиятуллин

**2.** *с. мәгъ.* Составында кеше организмы тукымасына берәр төс бирә торган матдә булган, пигментлы. *Көдрә кара чәчле, кара тут йөзле, күзләре күк йөзе кебек зәп-зәңгәр.* З.Мәхмүди. *Ә Нәфисәнең тут йөзе, затлы бүрегe астыннан бөдрәләнеп чыгып торган кара чәчләре, бит очы алмалары, иреннәре инде, иреннәре – кызыл күмәчләр...* Ф.Яхин

**ТУТ** II *и.* 1) Тутчалар семьялыгыннан яфракларын ефәк корты ашый торган көньяк агачы; ефәк агачы; *русчасы*: **тутовник**. *Аның әле байтак сөйлисе сүзләре калды, ул тут агачы яфрагын ашап ефәк бирүче коялырга бер дә туктамалды.* А.Алиш. *Алай дисәң бит, сине шунда ук сарайдан чыгарып, беренче очраган тут агачына асып куячаклар.* Ә.Еники

2) Шул агачның кура җиләгенә охшаган кызыл, ак, шәмәхә яки кара төстәге сусыл, татлы җимеше; *русчасы:* **тутовая ягода**. *Тут ашасаң, тешең буяла*

**ТУТА** *и.* Олы хатын-кыз кардәш; апа. *Ул баланың бер тутасы бар иде, моны ишетте дә энесенә әйтте: – Синең хәтереңдә бармы, абый безгә бервакытны бер сүз әйткән иде.* К.Насыйри. *Шулар белән син минем беренче тутам янына барып җитәрсең.* Н.Фәттах

**ТУТАЙ** *и.* 1) Сөйләүченең үзеннән олырак хатын-кыз; тәтәй. *Тутай кайткан.* Х.Туфан

2) Үзеннән олырак хатын-кызга олылап эндәшү яки атау сүзе (гадәттә исемнәрдән соң әйтелә). *Минем анайның бертуган энесенең – Әптел дәдәйнең уртанчы кызын синең әбиең Гайшә тутай белән тудык Бәлеш Усман малаена биргәннәр иде.* Ә.Еники. *Гәүһәршад бикә көйләп түгел, җитди итеп әйтте: «Тулдык мирза кызы Рәхилә тутай!»* Тарих эчләрендә ниләр бар?

3) Гомумән хатын-кыз. *Бу тутай наз өчен, бала табар өчен, йорт нуры өчен генә яралтылган.* Р.Батулла

**ТУТАЛЫ́-СЕҢЕЛЛЕ** *рәв. к.* **апалы-сеңелле**. *Туталы-сеңелле бу балаларны әбиләре үстерә.* Казан утлары

**ТУТАЛЫ-ЭНЕЛЕ** *рәв. к.* **апалы-энеле**. *Киленне туталы-энеле бик кыстыйлар.* Әкият. *Соңгыларыннан иң якыннары ике кечкенә дус – Нади һәм Дина исемле туталы-энеле ике ятим.* Ф.Баттал

**ТУТАШ** *и.* 1) Балалыктан чыккан яшүсмер кызларга һәм күбесенчә кияүгә чыкмаган җиткән кызларга эндәшү яки атау сүзе. *Тимерҗан, төшендә күргән кыз керер дип, ак күлмәкле һәр кызны җентекләп күзәтте, әмма серле туташ күренмәде.* Ф.Яруллин. *Ак халатлы туташ, нәрсәдер әйтергә теләгәнен күреп, аңа таба иелде.* Г.Галиев

2) Элек бай кызларына гына әйтелгән эндәш сүз. *Яшьтән үк Мәрьямнең колагына аның авыл кызларыннан өстенлеген, «Мәрьям туташ» булуын тукып торганнар.* Г.Ибраһимов

**ТУ́Т ЕФӘКЧЕСЕ** *и. зоол.* Кортлары тут агачы яфрагы белән туклана һәм үзләре чыгара торган ефәк җепләрдән кузылар ясый торган күбәләк; тут күбәләге; ефәк корты; *русчасы:* **шелкопряд тутовый**. *Бик борын заманнан Көнчыгыш илләрендә тут ефәкчесен үрчеткәннәр, аның кузыларыннан ефәк җитештергәннәр.* Биология. *Тут ефәкчесе – бик файдалы күбәләк. Аның гусеницалары ефәк ясый.* Зоология

**ТУ́Т КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол. к.* **тут ефәкчесе**. *Экдизон беренче тапкыр тут күбәләге курчакларында кабык салынуга китерә торган гормон буларак (гормон линьки) табылган.* Агулы үсемлекләр

**ТУТКЫЛ** *и.* **1.** *к.* **тут** I (*2 мәгъ.*). *Саргайдылар каен яфраклары, сары туткыл төште үләнгә.* Г.Латыйп

**2.** *с. мәгъ. к.* **тутлы** (*2 мәгъ.*). *Казарма ишеге төбендә аны какча озын буйлы, үзбәкләрнеке кебек ике чит-чите бераз гына югарыга тартыла төшкән кысык күзле, туткыл йөзле капитан көтә иде.* Җ.Дәрзаман. --- *Дегеттәй кара чәчләр, кара туткыл бит тиресе, куе кара кашлар, саз яшеле төсендәге зур күзләр.* Н.Көбәш

**ТУТКЫЛЛАНУ** *ф.* 1) Тут басу; туткыл төшү. *Йөзе туткылланган бу апаны беренче генә күрүе түгел иде малайның.* Казан утлары

2) *сир.* Кара яну, чырай караңгылану. *Бар да менә кара туткылланып, өскә җикерергә теләгән кебек торалар.* Г.Исхакый

**Туткыллана башлау** Туткылланырга тотыну; нәрсәнеңдер туткылланганы сизелә, күренә башлау. *Йөзе туткыллана башлаган*

**Туткыллана төшү** Бераз туткыллану; тагын да ныграк туткыллану. *Син дә күрдеңме, Әминәнең бите туткыллана төшкән.* Сөембикә

**Туткылланып бетү** Тәмам туткыллану. *Туткылланып беткән кулларыннан оялганга, озын җиңле күлмәкләр кия иде ул.* А.Галиева

**ТУТКЫЛЛЫ** *с. к.* **тутлы** (*2 мәгъ.*). *Бу сүзләрдән Карлыгач-Сылуның кара туткыллы сылу йөзенә, нечкә хәсрәт пәрдәсе белән өртелгән матур, кара күзләренә нур чәчелде.* Г.Ибраһимов. *Йөзгә кавказлыларга тартым, кара туткыллы кыз пакетының аяк астыннан юкка чыгуын сизмәде дә бугай.* Ф.Җамалетдинова

**ТУТЛАНУ** *ф.* Тут I төшү, тут (*1, 3 мәгъ.*) белән каплану. *Йөз пешә, кызган тимердәй тутланып.* Н.Исәнбәт. --- *тутланган йөзенә карaганда, яше шактый диеп уйлыйм мин аның.* Сөембикә

**Тутлана башлау** Тутланырга тотыну. *Бите тутлана башлаган*

**Тутланып бетү** Тәмам тутлану. *Болай да җилгә кәшәләп, язгы кояш нурларыннан тутланып беткән йөзе ютәлдән тагын да кызара төште.* Өмет

**ТУТЛА́У** *ф. диал.* 1) Җитенне, агарту өчен, карга җәеп калдыру, туңда тоту. *Җитен тутлау*

2) Юган керне, салкын ашап агартсын өчен, тышка элеп калдыру. *Мендәр тышларын тутлау*

**ТУТЛЫ** *с.* 1) Тут I (*1–3 мәгъ.*) төшкән, тут I чыккан, тут белән капланган. *Тутлы калай. Тутлы бит*

2) Билгеле пигментлы (тән, йөз тур.). *Алар арасында бер сары тутлы малай бар.* А.Алиш. *Ак кием аның кара тутлы йөзен, зур кара күзләрен аеруча ачыклап күрсәтә иде.* Г.Әпсәләмов. *Аның киң кара тутлы маңгаендагы нәзек кара кашлары матур булып җыерылды.* Х.Камалов

**ТУТНА́У** *ф. диал.* Уйнау (күз тур.)

**Тутнап тору** Әледән-әле, гел яки хәзерге моментта тутнау. *Булдыксыз буйга чатнап торган тел бирә, ди. Мие юк башка тутнап торган күз бирә, ди.* Мәкаль

**ТУ-ТУ** *иярт.* Паровоз, теплоход, машина, телефон һ.б.ш. сигнал биргәндәге яисә кайбер музыка коралларыннан чыга торган өзек-өзек тавышны белдерә. *Самуил Абрамович трубканы куйган, ту-ту дигән тавышлар гына ишетелә иде, ә Мансур әле һаман трубканы ычкындырмый басып тора.* Г.Әпсәләмов. *Өйрәнгән теге бәләкәй чакта би-би, ту-ту дип машина белән уйнарга!* Н.Кәримова

**ТУ́ТЧАЛАР** *и. күпл.* Тропикларда һәм субтропикларда киң таралган, күбесенчә сөтле сыекчалары булган һәм кайберләре ашарга яраклы җимеш бирә торган агач, куак кебек үсемлекләрнең 1500 дән артык төрен берләштергән семьялык. *Тутчалардан (тутовые) гади колмак (хмель обыкновенный – һумулус лупулус L.) күркәләре составында сөткә әче тәм бирүче эфир майлары бар (1–3%).* Агулы үсемлекләр

**ТУТЧЫЛЫК** *и.* Тут агачы үстерү белән шөгыльләнә торган ефәкчелек тармагы; тут ефәкчелеге. *Тутчылык тармагы*

**ТУТЫГУ** *ф.* 1) Тутык белән каплану. *– Тик торган сөңге тутыга ул, углан, аны һәрвакыт кулда тотарга кирәк, – дип, хан ният пәрдәсенең бер почмагын күтәребрәк куйды.* М.Әмирханов. *Дымлы, зәһәр газлар белән нык пычранган һавада тимер коррозиягә тиз бирешә, тутыга.* Төзү материаллары

2) Күп вакыт үтү сәбәпле тоныклану, ялтыравыгын югалту. *Тутыккан көзге без, Җәмшид җамы без.* Г.Хәйям

3) *күч.* Боегу; төссезләнү; чисталыгын, сафлыгын югалту (күңел, хис һ.б.ш. тур.). *Бикчәнтәй агай, я әле, булмаса, тутыккан күңелләрне нечкәртеп уйнап-җырлап җибәрегез.* Т.Гыйззәт. *Мәхәббәт чишмәсе саекса, хисләр тутыга.* Н.Гыйматдинова

**Тутыга бару** Аз-азлап, акрынлап тутыгу. *Шушы уйлар белән йөргәнендә, ул үзенең күңеле тутыга барганлыгын тойды.* Ф.Яхин

**Тутыга башлау** Тутыгырга тотыну. *Карап тормасаң, хәзер бозыла, тутыга башлый...* М.Галәү. *Бәлки, чыннан да, шулайдыр: мәктәптә җиде ел буена кермәгәнне тутыга башлаган шарикларга сугыш җиде көндә сеңдерә торгандыр.* Н.Әхмәдиев

**Тутыга төшү** Тагын да күбрәк тутыгу. *Йозак тагын да тутыга төшкән*

**Тутыгып бетү** Тәмам, тулысынча тутыгу; тутыккан хәлгә килү. *Кайларда аунап яткан инә булгандыр, тутыгып беткән иде ул.* Ә.Моталлапов. *Тимер рәшәткә бөтенләй тутыгып беткән: нинди төскә буялганын да белерлек түгел иде.* Ф.Абдуллин

**Тутыгып яту** Озак вакытлардан бирле тутыгу. *Гамилләр келәтендә бер әрҗәдә әллә никадәр шөреп, гайкалар тутыгып ята икән.* А.Тимергалин

**ТУТЫГУЧАН** *с.* Тиз тутыга торган; коррозиягә бирелә торган. *Кемнәрдер уалучан, тутыгучан, бик тиз сынучан әйберләрне күбрәк җитештергән саен, без – гади халык, үзебез дә сизмичә, кабалага төшә барабыз.* Шәһри Казан

**ТУТЫГУЧАНЛЫК** *и.* Коррозиягә бирелүчән, тутыгучан булу

**ТУТЫЙ** *и. фар. зоол.* 1) *к.* **тутыйкош**. *Кулга моның кебек тутый керер дип, бик куанып, алтын күндереп, тутыйны сатып алды.* М.Гайнетдин. *Нәрсә калган инде бу сабыйга, дип уйлап та өлгермәдем, ул яшел тутый утырган читлек янына барып та басты.* Г.Гыйльманов

2) *күч. шелт.* Үз фикере булмыйча, башкаларның сүзен, фикерен кабатлаучы, кешегә ияреп эш итүче кеше. *Кем булсын, шул койрыксыз тутый Фәхрия инде.* Г.Сабитов

◊ **Тутый тоту** *к.* **тутыйкош тоту**. *[Сәфәргали:] Эшләрең шәптән түгел бит. [Тимерче:] Синең дә әле тутый тотканың күренми.* К.Нәҗми

**ТУТЫЙКОШ** *и. зоол.* 1) Тутыйкошлар семьялыгыннан тропик һәм субтропик урманнарда яши, өй шартларында да асрала торган аллы-гөлле каурыйлы, кеше сөйләмен кабатларга сәләтле кош; **попугай**. *Паркның аллеяларында да тутыйкошлар төрле позаларда көязләнеп йөреп тора.* М.Мәһдиев. *Хәтта читлектәге тутыйкошлар да тынып калган.* Ф.Яруллин

2) *күч. мыск.* Кәпрәеп, эреләнеп йөрүче кеше. *Бу тутыйкош, ичмасам, аларның гаепләү актларын укып чыкканмы соң?* И.Сиражи. *Бетмәс монда синең кебек тутыйкошлар, башкаларны да хөрмәт итәргә өйрән башта.* Казан утлары // Киемнәре белән башкалардан аерылып тора торган, гадәттә, купшы, чуар киенгән кеше. *Булмәгә төз гәүдәле, ыспай киемле бер чибәр углан килеп керде. Һәммәсе карашы белән угланны капшый, янәсе, нинди тутыйкош бу?* М.Әмирханов

3) *күч.* Ир-атларның күзе төшә торган яшь, чибәр хатын-кыз. *Ходай миңа шушындый татлы тутыйкошларны күбрәк бирсен иде дә аларның иркәназыннан бер генә минутка да аермасын иде.* В.Имамов. *Әмма мәгърур ир катында тутыйкош булып утыру барыбер бик тә килешә үзенә.* Р.Мулланурова

◊ **Тутыйкош белән чыпчыкны бер өйдә тоту** Тиң булмаганнарны тиңләштерү турында. *Юк инде ул, егет, тутыйкош белән чыпчыкны бер өйдә тотармын димә син. Бармак та тигез түгел.* Ф.Хөсни. **Тутыйкош каурыена төренгән карга** *мыск.* Үзен акыллы, белемле һ.б.ш. сыйфатларга ия итеп күрсәтергә тырышып йөрүче кеше. **Тутыйкош тоту** Көтмәгәндә берәр уңышка ирешү, берәр нәрсәгә ия булу. *Путин ил белән идарә иткән вакытта ике татар фамилияле кешенең министр булуын тутыйкош тоткан кебек бәяләп кабул итүчеләр дә булды: менә бит, Путин татарларны ярата...* Р.Латыйпов

**ТУТЫЙКОШЛАР** *и. күпл. зоол.* Тутыйкошсыманнар отрядыннан тутыйкош, лори, ара һ.б.ш. кош төрләрен берләштерә торган семьялык атамасы; *русчасы:* **попугаевые**

**ТУТЫЙКО́ШСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Тропик һәм субтропик урманнарда тереклек иткән купшы каурыйлы, төрле төстәге кошлар керә торган тутыйкошлар, какадулар семьялыкларын берләштергән кошлар отряды; *русчасы:* **попугаеобразные**

**ТУТЫЙЛАНУ** *ф.* Үз фикере булмыйча, кешегә иярү; кеше фикерен, кыланышын, сүзләрен кабатлау; попугайлану. *Тутыйланырга ярату*

**ТУТЫК** *и.* **1.** 1) Су яки дымлы һава тәэсире нәтиҗәсендә металл өстендә барлыкка килә торган кызыл көрән кунык. *Рөстәм утынлыкта аунап, шактый тутык капларга өлгергән балтаны бүкәнгә кадап куйды.* Ф.Яруллин. *Тутык баскан калай юынгычка иелеп, краннан учына җылымса, ничектер лайлалы тоелган болганчык су агызды, кызган муенын, арт чүмечен сөрткәләде.* М.Маликова

2) Саз суына көрәнсу төс һәм үзенчәлекле тәм бирә торган тимер әчесе; черек

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тутыкланган, кунык каплаган, кунык чыккан. *– Эх, гомер – тутык тимер! – диде берсе, тәмәкесен төкереп.* Х.Камалов. *Бар да тутык, иске, җимерек.* З.Зәйнуллин

2) Тутыклы; черек; тутык катнашкан, тутыгы булган. *Шыксыз сазлыкның тутык мүкләре арасында сары сулы күлчекләр торган саен ешрак күренә.* Г.Әпсәләмов. *Кып-кызыл тутык су килә башлады, ләкин анысы да ирепеп кенә ага иде.* Казан утлары

3) *күч.* Тоныклана башлаган. *Алар арасындагы мөнәсәбәт, гомумән, мәктәп елларыннан калган тутык истәлекләрдән, очрашкан чакларда әйтелә торган «исәнме-саумы» кебек сүзләрдән ары узмый иде.* Н.Фәттах

**ТУТЫ́К ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Үсемлекләрдә барлыкка килә һәм, үрчеп, черек авыруы тудыра торган вак паразит гөмбә; *русчасы:* **ржавчинный гриб**. *Тутык гөмбәләр басу гөмбәләре төркеменә керәләр һәм тамырда үсә торган аерым төр яшел үсемлекләрне зарарлыйлар.* Агулы үсемлекләр

**ТУТЫКЛАНДЫРУ** *ф.* Тутыклы итү; тутыклыга әйләндерү. --- *ул маңгай шәрәләндерүләре, йөзенә уйчанлык билгеләре чыгарыр өчен, усал карашлы күзләрен төпкә батырулары министрны киресенчә ахмак итеп күрсәтә, шәхесенә карата хөрмәт хисен тутыкландыра иде.* Ф.Яхин

**ТУТЫКЛАНУ** *ф.* Тутыгу, тутык белән каплану; тутыкка әйләнү. *Араларыннан барс композициясен генә калдырачаклар: тутыкланса да, республика символы бит ул.* Ватаным Татарстан

**Тутыклана башлау** Тутыклану билгеләре күренү. *Тимер тутыклана башлаган*

**Тутыклана төшү** Бераз гына тутыклану; тагын да күбрәк тутыклану

**Тутыкланып бетү** Тәмам тутыклану

**ТУТЫКЛЫ** *с.* Тутыгы булган; өсте тутык белән капланган. *Краннан тутыклы сары су килә иде...* Г.Әпсәләмов. *Һәрбер зат үз аслына кайтмый калмас, Тутыклы булат кылыч та чапмый калмас.* Ю.Сафиуллин

**ТУТЫКЛЫК** *и.* Тутык катнашу, кушылу; тутыгу дәрәҗәсе. *Суның тутыклыгы*

**ТУТЫКМАС** *с.* 1) Тутыкмый, күгәрми торган. *Тутыкмас корыч*

2) *күч.* Бозылмый, җимерелми торган. *Тутыкмас дуслык*

**ТУТЫКТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тутыгу**

2) *күч.* Боектыру, боекландыру (мәс., күңелне)

**ТУТЫ́К ҮЛӘНЕ** *и. биол.* Башаклылар семьялыгыннан күпьеллык үлән; чәчбай; *русчасы:* **вейник**. *[Тугайлыкларда] еш кына тал, сары люцерна, тутык үләне кебек үсемлекләр үсә.* А.Фәткуллин

**ТУТЫРМА** *и.* 1) Тапалган үпкәбавыр һәм ярма катнашмасын юан эчәккә салып пешерелгән казылык; сукта. *Борынгы язмаларда «сукта» дигән сүз бар, мәгънәсе – тутырма, ягъни эчәккә ит яки башка продукт тутырып пешерелгән ашамлык.* Л.Җәләй. *Шунда ук кечкенә блокнотына бу тутырма дигән хикмәтнең ничек эшләнүен сорашып, язып та алды.* Ә.Еники

2) Эчәккә, тавык тиресенә һ.б.ш. нәрсәләргә эчлек тутырып әзерләнгән ашамлык. *Тавык жаркоеннан соң тавык муенының тиресенә тавыкларның бүтәкәләрен, йөрәкләрен тапап тутырган тутырма кирә.* К.Тинчурин. *--- төрлечә әзерләнгән балык, шулпа, шашлык, кыздырылган баклажан, тутырма – барысы да даими рәвештә үз тәлинкәләре белән өстәлдә урын ала торды.* Т.Галиуллин

**ТУТЫРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тутыру**. *Анкета тутырттылар.* Х.Камалов. *Инде дөньяның хәл-хәбәр чараларыннан мәгълүм булганча, ул корабка бик күп аракы тутырткан иде.* Ф.Баттал. *Икенче урында бәрәңгене капчыкларга тутырттылар.* Х.Ширмән

**ТУТЫРУ** *ф.* 1) Нинди дә булса сыешлыкны нәрсә беләндер тулы итү. *Тукал, урта өй каршысында зур казан тутырып, ит пешерә.* Г.Ибраһимов. *Аларның кыланмышларын карап тору Хариска кызык тоелды: егетләр кырлы стаканны тутырып утлы суны бер сулышта йотып куялар да иписез-нисез чучка мае кабалар.* А.Фәләх

2) Берәр әйбер эченә башка ваграк нәрсәләр яки сыеклык салу. *Шул шакмакларны капчыкка тутырдылар һәм кухняга китерделәр.* Х.Камалов. *– Санаулы көн тиз үтә шул, кайтуың кая да, китүең кая, – дип, кызының сумкасына күчтәнәчләрен тутыра-тутыра, Сәвия үзалдына сөйләнеп куйды.* Г.Бәйрәмова. *Малай башта зур гына бер «Сникерс» тартып чыгарды, аннары борчак конфетларны, учлап алып, кесәсенә тутырды.* Л.Гыймадиева

3) Анкета, бланк һ.б.ш. шундый кәгазьләрнең тиешле урыннарына мәгълүматны язып кую, теркәү. *Тикшерүләрне тәмамлау турындагы документны дәүләт куркынычсызлыгы органнары кече лейтенанты икенче бүлек оперуполномоченные Мөхәммәтҗанов тутыра.* Р.Мөхәммәдиев. *Дәүләтшин өстәл артында авыру тарихы тутырып утыра иде, профессор кергәч, аягүрә басып, халатын тарткалады.* М.Маликова

4) Нәрсәнедер сан, комплектлылык һ.б.ш. ягыннан тиешле дәрәҗәгә җиткерү, тулыландыру. *Ставка карамагында булачак 469 нчы миномёт полкы сафларын Котлубаньнан килгәннәр дә тутыра алмады.* С.Поварисов

5) *кулин.* Ризык әзерләү барышында берәр нәрсәнең (мәс. баклажанның, борычның һ.б.) алдан чистартылган эчке куышлыгына яисә кошларның тиресе белән ите арасына ит, йомырка яки башка эчлек салу. *[Гөлҗамал тәтәйләрнең] Кияүләре килгән икән, тавык тутыралар.* К.Тинчурин. *Алдан әзерләп куелган борычларны шул итле эчлек белән тутырабыз.* Сөембикә

6) Берәр ис, газ һ.б.ш. нәрсәләр бик нык җәелдерү, таралу. *Хатын-кыз мәш килә, майлы таба исе урамны тутыра, күңелле була.* М.Мәһдиев. *Әз генә таудан менә башласаң да, котырган ишәк тавышлары чыгарып акырырга тотына, кабинага төтен тутыра.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Бөтен тирә-юньне, барлык буш урынны биләп алу, бөтен тирәюньгә, барлык урыннарга таралу; күп булу. *Ул әйтеп тә бетермәде, киң урамны тутырып, соры күлмәк кигән, фашистлар значогы таккан бик күп кешеләр уза башлады.* А.Алиш. *--- күзләрен йорт казларының урам тутырып каңгылдашып очарга маташулары күз алдына килә, салам түбә кыегына оялаган чыпчыклар, өянке башларындагы карга оялары – һәммәсе шундый якын, шундый кадерле.* Ф.Яруллин

8) *күч.* Билгеле бер өслекне, урынны, бушлыкны биләп, тулысынча каплап алу. *Иргали сәкене тутырып йоклаган балалар янына килде.* М.Хәсәнов. *Сәхнәне тутырыр кеше кирәк иде.* Р.Батулла. *Анда өстәл тутырып бәйрәм табыны әзерләп куелган!* М.Вәли-Барҗылы

9) *күч.* Билгеле бер урынга кешеләрне, җанлы-җансыз нәрсәләрне күпләп кертү, урнаштыру. *Ачлыкка түзә алмыйча, балаларына ашатырга бер уч арыш алып кайткан аналарны төрмәләргә тутырдылар, тик халык урлашудан туктамады.* Т.Миңнуллин. *Кешеләрне электробусларга тутырып крематорийларга яккан дөньяда тыныч тормыш турында хыяллану аңа сәер булып күренде.* М.Кәбиров

10) *күч.* Берәр нәрсәне күп итеп кемгәдер бирү, кая булса кайтару, илгә кертү һ.б.ш. *Иң сыйфатсыз товарны безгә тутырачаклар, дидем бит.* Казан утлары

11) *күч.* Тирә-якка җәелү, яңгырап, яхшы ишетелү (тавыш, шау-шу тур.). *Һәм, өй эчен тутырып, Сауараның җыры яңгырады: «...Шулай да Кайтырсың шикелле тоела».* М.Хуҗин. *Борынгы дулкынландыргыч көй бөтен тирәлекне тутыра, бәхет иллюзиясе туа.* Р.Хуҗин

12) *күч.* Барлыкка килү; биләп алу (хис, фикер, тойгы һ.б.ш. тур.). *Көтелмәгән бу вакыйга минем йөрәгемне ашкыну белән тутырды.* Һ.Такташ. *Шушындый гүзәл, ак хыяллы, нечкә, пакь җанлы бер хатынның якын, ышанычлы кешесе булу аны ничектер үз күз алдында үстереп җибәрә, күңелен әйбәт бер горурлык белән тутыра иде.* Ә.Еники

13) *күч.* Таләп ителгән эшне тиешле күләмдә үтәү. *Солдат хезмәтен тутырып кайткан егет иде ул.* Г.Сабитов. *Нормагызны тутырып кайтсагыз, берәр пот он бирербез.* Ф.Яруллин

14) *күч.* Билгеле бер чиккә, санга җитү (яшь, вакыт, мөддәт тур.). *Ходай кушса, тиздән унны тутыра инде.* М.Хәсәнов. *Алтынчы дистәсен тутыра кеше.* С.Сабиров. *Картайды инде, картайды ул да, җитмеш бишен тутыра.* Р.Сәгъди

15) *күч.* Баету; канәгатьләндерү; тагын да тулырак итү (рухи тормыш

тур.). *Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде.* Ә.Еники. – *Эш кенә күңел бушлыгын тутыра алмый, шәхси тормышта бәхетсез кешеләр эшләрен дә әйбәт башкармый, – ди йөрәк.* Ф.Яруллин

◊ **Тутырган тавык** Тулы, тыгыз, ак тәнле хатын-кыз турында әйтелә. *Теге ни, тутырган тавыгыма тәмле йокылар телә, күрше.* Н.Гыйматдинова. **Тутырган тавык кебек** *к.* **тутырган тавык**. *Аның артыннан ук баскычка әткәй, әткәйгә ияреп, тутырган тавык кебек таза Сәрия апа чыгып басты.* Ш.Җиһангирова. **Тутырган тавык төсле** *к.* **тутырган тавык**. *Нәшриятта дүртенче катта машинистка булып тутырган тавык төсле тулы гәүдәле бик матур ханым – Әминә апа эшли иде.* А.Хәсәнов

**Тутыра бару** Берсе артыннан берсен тутыру; акрынлап, аз-азлап тутыру. *Ялчы шуларны түбәнгә ыргыткан, ә бай аларны, җыеп, капчыгына тутыра барган.* А.Алиш. *Киңлек уяткан уйлар, истәлекләр бушлыкны тутыра бара.* Ш.Галиев

**Тутыра башлау** Тутырырга тотыну. *Бал-майларыгызны тәпәнгә тутыра башлагыз, кызыбызга исем куштыру бәйрәме үткәрергә җыенабыз.* Ф.Яруллин. *Мин боларны берәм-берәм сулы мичкәгә тутыра башладым.* А.Хәсәнов

**Тутыра бирү** Тутыруын дәвам итү; һаман да тутыру. *Бюрократның начарлыгы хакында ни күрде, шуны карынына, ялгыш әйттем, башына тутыра бирә.* Г.Камал

**Тутыра килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә тутыру. *Аның буш, билгесез калган урыннарын акрынлап башка галимнәрнең һаман тутыра килүе әнә шул хакта сөйли.* Р.Низамиев

**Тутыра тору** Нindидер эш башланганчы тутыру. *Бар, атны алып кил, мин тутыра торырмын.* А.Алиш

**Тутыра төшү** Бераз гына тутыру, тагын да күбрәк тутыру. *Аталарының тәртипсезлеген балалар тагы тутыра төшкәннәр. Аның китаплары, журналлары арасында актарынганнар.* Г.Ибраһимов

**Тутыра язу** Чак кына тутырмыйча калдыру. *Ул кырлы стаканга аракыны тутыра язып салды.* Ә.Еники. *Зәнфирә, бер шешәне ачып, зур кружкага тутыра язып сыра салды һәм Ирекне иңбашыннан тотып торгызды.* Ф.Садриев

**Тутырып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә тутыру. *Юра кулындагы фонарен Сашага сузып: «Син яктыртып тор, мин хәзер банканы тутырып алам», – дип, фонарьны бирде дә стенадагы теге чүмечкә үрелде.* Р.Сәгъди

**Тутырып бару** Эзлекле рәвештә тутыру. *Заданиесен адәм төсле тутырып барсын әле. Заданиесен дә тутырсын, безгә дә арттырсын, вәт ул колхоз фермасы булыр!* Ә.Еники. *Иң рәнҗеткәне шул булды: безгә, өч кызга, бирнәгә дип әни сандыкка тутырып барган чүпрәк-чапракка кадәр калдырмадылар, дип искә ала Нәҗип аганың өлкән кызы Люция.* Л.Шәех

**Тутырып бетерү** Тулысынча тутыру, буш урын калдырмыйча тутыру. *Ләкин комсыз хатын-кыз булса, бу кыйммәтле нәрсәләр белән бөтен кесәләрен, изүләрен тутырып бетерә.* К.Насыйри. *Имеш, өч литрлы банкага биш кило бал сыймый, син шуны да тутырып бетермисең.* Ф.Яруллин

**Тутырып җибәрү** Тиз генә тутыру. *Ну, кызлар, әйдәгез, комганнарыгызны җиләк белән тутырып җибәрик.* Һ.Такташ

**Тутырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәгә җиткәнче тутыру. *Базарда сыйфатсыз ризык биреп җибәрәләр, акчаны кысып калалар, килоны тутырып җиткермиләр дип, күпләр азык-төлек, башка вак-төякне кибеттән, супермаркеттан ала.* Татарстан яшьләре

**Тутырып килү** Тутыру алдында тору. *Хәзер безнең балалар өч яшьне тутырып килә бит.* Ф.Яруллин. – *Әйдә, түрдән уз! – диде сигез дистәне тутырып килсә дә һаман да җиңел, җыйнак гәүдәле карчык, өстәл арасыннан күтәрелеп...* Г.Галиев

**Тутырып кую** Тиз арада яки алдан тутырылган хәлгә китерү. *Хәзер үк авылга кайтып китәсең дә алты йөз центнер ашлыкны капчыкларга тутырып куясың.* Т.Гыйззәт. *Ягылмаган өйдә өшер ату, базыңа тутырып куй.* В.Нуруллин

**Тутырып ташлау** Кинәт, күп итеп тутыру. *Бишьеллык план бетүгә, товар белән дөньяны тутырып ташларбыз.* Т.Гыйззәт

**Тутырып тору** Хәзерге моментта тутыру; әледән-әле, еш, бертуктаусыз тутыру. *Баш очында – калынкаш бабайның дәү рәсеме, ярты стенаны тутырып тора.* А.Гыйләҗев. *Шулай да аның күңелен берөзлексез шатлык һәм куаныч тойгысы тутырып торды.* Н.Фәттах

**Тутырып утыру** *к.* **тутырып тору**. *Госман өй тутырып утырган яшел массага бер секундка гына күз ташлады: ә бит чыннан да шулай булуы мөмкин, шайтанның.* М.Мәһдиев

**Тутырып чыгу** Берсен дә калдырмыйча, һәрберсен тутыру. *Шуннан соң тирмә почмагында торган тире капчыктан касәләргә әче бал тутырып чыкты.* Р.Сәгъди

**Тутырып яту** *к.* **тутырып тору**. *Шулай байтак вакыт үткәч, Дүрткүз остаз дустының биштәренә әйберләр тутырып ятканын күрде.* Р.Батулла. *Тик өченче көн дигәндә, эштән кайтуына, Рамил теге даруларны сулы чынаякка тутырып ята иде.* М.Кәбиров

**ТУТЫРУК** *с. диал.* **1.** Туп-тулы; тәмам тулы. *Театр тутырук иде.* Г.Бәширов

**2.** *хәб. функ.* Туп-тулы хәлдә. *Мәктәп бакчасы тутырук яшелчәң – кыярын, кәбестәсен шуннан ташырсың.* Н.Гыйматдинова. *Аллага шөкер, өйләре тутырук май, сыр, эремчек...* А.Гыймадиев

**3.** *рәв. мәгъ.* Бик күп. *Әле яңгыр туктамады, инде бөтен чиләкләр тутырук булды.* Казан утлары

**ТУТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **тутыру** (*1–3 мәгъ.*). *Чыннан да, землянканың үзләре салкынчарак диеп уйлаган бер почмагында зур арыш капчыгына тутырылган бәрәңге җир идәнгә бастырып куелган иде.* М.Вәли-Барҗылы. *Ул затлы товарлар белән шыплап тутырылган була.* М.Кәбиров

**ТУТЫРЫНУ** *ф.* Бик нык, артык күп тутыру. *Бер атнага җитәрлек итеп тутырынганмын.* В.Исламетдин

**ТУТЫРЫП** *рәв.* 1) Зур, киң итеп ачып (күз, авыз тур.). *Проводница мул авызын тутырып елмайды да, ачкычларын шылтырата-шылтырата, Искәндәргә эндәште: – Бара тор, хәзер килермен.* Р.Вәлиев. *Ул, беткән баш беткән инде дигән кебек, карчыкларның төпсез, нурсыз күзләренә беренче мәртәбә тутырып, батырып карады.* Г.Гыйльманов

2) Мөмкин булган кадәр киң итеп; ахырына кадәр (ишек, тәрәзә, капка һ.б.ш. кебек ачыла торган әйберләрне ачу тур.). *Ишекне тутырып ачып, Сәлимә керде.* Н.Гыйматдинова. *Ишекне, тәрәзәне тутырып ачтылар, аннан салкын һава кереп тулды.* Казан утлары

3) Тулы итеп; тулысынча; бер сүзен яки авазын да төшереп калдырмыйча; бөтен тулылыгы белән. *Ибраһим дип тутырып әйткән кеше юк инде бездә.* Р.Вәлиев. *«Бисмилла» дигән сүз белән генә чикләнмичә, әбисе өйрәткәнчә тутырып әйтә ул бу доганы: «Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-ражим...»* Г.Гыйльманов

4) Сүзне читләтеп түгел, турыдан-туры, гадәттә тупас итеп әйтү турында. *Миңзаһит, барысын да тутырып әйтмәкче булып, Лира ачуын алырга теләсә дә тыелды.* Ф.Садриев

**ТУТЫШ** *и. диал.* Пешкән ит салып ясала торган пәрәмәч. *Яңа пешкән тутыш*

**ТУТЫЯ** *и. фар.* 1) Аксыл күк төстәге металл; цинк. *Ике ел элек, Галияр солдатка китәсе елда, йортны бакча ягына тагын бер торыкка үстергәч, Тимерша түбәне тоташтан тутыя калай белән япты, акчасын кызганмады.* М.Хуҗин. *Ул мур кыргыры (мородёр) байлыкны туган илгә ничек алып чыга диген әле. Тутыя табутта!* Р.Сәгъди

2) Цинк кушып ясалган күз даруы. *Тутыя – күзгә шифа.* Әйтем

**ТУУ** *ф.* 1) Дөньяга килү. *Сугыш беткәннән соң нәкъ өч елдан мин туганмын.* Н.Нәҗми. *Була бит шундый гаделсезлек: адәм баласы анадан туганда ук зәгыйфь булып туа.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Берәр күренеш барлыкка килү, килеп чыгу, пәйда булу, формалашу. *Шуңа күрә бездә милли мәгариф тә, милли университет та, татар фәне дә, татар җәмгыяте дә, ахыр чиктә татар дәүләте дә туа алмый.* И.Әмирхан. *Бар хаталар, үпкәләр, үткәннәр, рәнҗегән кешеләр бирелдә кала – яңа урында тормышны өр-яңадан башлап җибәрергә мөмкинлек туа.* М.Маликова

3) *күч.* Уяну, яңару, барлыкка килү (хис, уй һ.б.ш. тур.). *Һөҗүм башланган көннән үк аның уңышлы узуына шик туды.* З.Зәйнуллин. *Бу бик матур кешегә – олы язучыга карата ихтирамым, мәхәббәтем шул чакта ук туды.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Башлану, килү. *Син монда бик моңайма, төн артыннан көн туа, дип әйтә торганнар иде безнең авыл картлары.* Г.Әпсәләмов. *Таң туа офыкта алланып.* С.Якупова

5) *күч.* Яңа стадиягә керү. *– Аннары шул: сигез көннән, кияү, төн үзәге авышкач, беренче әтәч кычкырыр алдыннан, яңа ай туа, – диде Утташ кам, ашыкмыйча гына, күзләрен йома төшеп.* Н.Фәттах

◊ **Тумаган балага бишек кору** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Муллалар, үз мәхәлләсендә ничә кыз бирeләчәген, ничә килен ярәшеләчәген күптән санап куеп, ничаклы никах вә садака акчасы керерен әллә кайчаннан хисаплап, тумаган балага бишекләр корып беткәннәр иде.* Г.Ибраһимов. **Тумаган балага бишек элү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган балага бишек элмиләр.* Мәкаль. **Тумаган балага бишек ясау** Әле эшләнмәгән эшнең нәтиҗәләре турында фараз итү, нигезсез планнар кору; алдан шапырыну, мактану. *Үзегез дә беләсез: тумаган балага бишек ясамыйлар.* И.Нуруллин. **Тумаган балага күлмәк алу** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган балага күлмәк алу кебек була инде бу.* Татарстан яшьләре. **Тумаган балага күлмәк тегү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Алай да, яхшылап уйлап карагыз әле, чөнки «тумаган балага күлмәк текмиләр» диләр андый очракта.* Сөембикә. **Тумаган тайга атлану** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган тайга атланма, билен сындырырсың.* Әкият. *Тумаган тайга атлану шул үзе була инде.* З.Мәхмүди. **Тумаган тайга йөгән кидерү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Аннары халыкта «тумаган тайга йөгән кидермиләр» дигән бик мәгънәле әйтем барлыгын да онытмасак иде.* Кызыл таң. **Тумаган тайга йөгән үрү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган тайга йөгән үрмиләр.* Мәкаль. **Тумаган тайга йөгән ясау** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган тайга йөгән ясый торган заманнар үтте инде.* М.Мәһдиев. **Тумаган тайга каеш камыт** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Ничек инде, иптәш Харисов, тумаган тайга каеш камыт, дигән кебек була түгелме соң бу?* Р.Төхфәтуллин. **Тумаган тайга нукта үрү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган тайга нукта үрмә.* Мәкаль. **Тумаган тайны дагалау** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган тайны дагаламыйлар.* Мәкаль. **Тумаган тайны иярләү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. **Тумаган колынның билен сындыру** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Чыннан да, тумаган колынның билен сындыргандай кебегрәк булды.* Казан утлары. **Тумаган тайның билен сындыру** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Халык мәзәгендәгечә, без тумаган тайның билен сындырган булганбыз.* Ә.Баян. *Ярый, тумаган тайның билен сындырмыйк, алдагы уңышлар өчен бер дога.* Г.Каюмов. **Тумаган тайның бил сөяген сындыру** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. **Тумаган туры алашаның бил сөяген сындыру** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Тумаган туры алашаның сөяген сындырмыйлар.* Мәкаль. **Тумаган тайның тиресен бүлешү** *к.* **тумаган балага бишек ясау**. *Алар һаман тумаган тайның тиресен бүлешәме?* В.Имамов. **Тумас борын** Бик иртә; вакытыннан алда; яшь килеш. *Тумас борын тәмәке тарталар, тумас борын аракы чөмерәләр хәзер яшьләр.* З.Мәхмүди. **Тумас борын картайган** Үз-үзен тотышы картларча булган яшь кешегә карата әйтелә. *Ләкин күп тә үтмәде, көлепелмаеп, хушбуй исләре аңкытып, аның каршысына Зәкия килеп басты; җиңел*

*генә аның кулыннан алды да, шелтә дә, үпкә дә белдергән бер кыюлык белән: – Тумас борын картайгансың икән, Һарун!* Н.Фәттах. *– Тумас борын картайгансың син, – дип, дорфа гына аның сүзен бүлде Ихтыяр.* Р.Вәлиев

**Туа бару** Бер-бер артлы туу; эзлекле рәвештә туу. *Балалары туа барды, үлә барды.* З.Зәйнуллин. *Тавыш чыгарган: имеш, туа барган бәрәннәрне дәфтәргә теркәп алып, колхоз кенәгәсенә кертмәгән Зариф.* Ф.Яхин. *Янә күңелдә әрнүле ризасызлык туа бара.* Гасырлар авазы

**Туа башлау** Туу алдында тору, туарга тотыну. *Нәрсә бу: кыз үзе миңа йөзен борганга күрә генә туган хисләнүме, әллә чын яратуның туа башлавымы?* Ә.Еники. *Бераздан, Фәкилә апаны гаҗәпкә калдырып, күңелдә ниндидер тезмәләр туа башлады.* Г.Рәхим

**Туа килү** Электән үк, күптәннән бирле барлыкка килү. *Минем күңелдә туа килгән бушлыкны эретерлек матур сүзләр әйтеп калдырчы.* Т.Галиуллин. *Элек ул, клиника миннән башка яши алмый, дип уйлый иде, ә хәзер клиниканың аңардан башка да бик шәп яши алганлыгын күрә, аның элекке традицияләре әкрен-әкрен сүнә барып, яңалары туа килә.* Г.Әпсәләмов

**Туа тору** Әледән-әле туу. *Радиация дип тормады, балалар туа торды, аякка баса торды, дөньяга тарала торды.* Ф.Бәйрәмова. *Шагыйрьләр туа торырлар, Туфаннар булмас инде.* К.Сибгатуллин

**Туып килү** Туу алдында тору, сизелә, беленә башлау. *Без, язучылар, халыкның элекке тел хәзинәсеннән файдалану белән бергә, күз алдыбызда туып килә торган ул яңа сүзләрне дә вакытында ишетә һәм куллана белергә тиеш.* М.Хәбибуллин. *Бу җәрәхәт янында икенче бер җәрәхәт туып килә...* Г.Гыйльманов

**ТУФ** *и. лат.* **1.** Төзү материалы буларак кулланыла торган күзәнәкле вулканик яки утырма тау токымы. *Вулкан атканнан соң, җиргә коела торган көл грекча «тефра» дип, вулкан көле катканнан соң хасил булган таш «туф» дип атала.* Н.Фәттах. *Ватылган тау токымнары көпшәк (вулканик көл, вулканик ком) һәм береккән (вулканик туф, кубекташ, туф лавасы) төркемнәренә бүленә.* Төзү материаллары

**2.** *с. мәгъ.* Туфтан эшләнгән, туфтан ясалган. *Туф йорт*

**ТУФАН** *и. гар.* 1) *дини* Нух пәйгамбәр заманында җир астыннан чыккан су һәм күктән яуган яңгыр сәбәпле бөтен дөньяны су басу. *--- туфан чыгасын белеп, Нух пәйгамбәр зур көймә ясаткан, һәм туфан чыгып бөтен дөньяны су басканда, үзенең якын кешеләре белән көймәдә котылып калган.* Н.Фәттах. *Ходай, ачуланып, туфан китергән, кешеләрне батырган.* А.Садыйкова

2) Бик көчле яңгыр, су ташкыны, су басу. *Ил кадәр илне юк итте бит, гүя туфан калыкты, гүя туфан, дөньяны су басты.* М.Хәбибуллин. *Безнең бабайларның сөйләүләре буенча, алар Урал тауларында туфан үткәнне көтәләр.* Ф.Бәйрәмова

3) Тузан, ут өермәсе, ком яки кар бураны. *Ноябрь чыгып җиткәне юк әле, шулай да дөнья кар туфаны астында калып, җир йөзен тирән көрт басты ---.* Г.Ибраһимов. *Аннан соң туфан калыкса да куркыныч түгел.* М.Әмирханов

4) *күч.* Нәрсә дә булса бик күп булу, берәр нәрсә ташкыны; ташкын, көчле агым. *Су астыннан караган сыман: рухи дөньяны яшь туфаны баскан.* Ш.Галиев. *Кайнар кан туфаны күтәрелә.* Ф.Гыйззәтуллина

**ТУФЛИ** *и. гр.* Аякның тубык сөягеннән түбән өлешен генә каплый торган сай аяк киеме. *Чөнки чыршылар янына кар ерып керергә кирәк, ә Фәләхнең аягында шәһәр көязләре киеп йөри торган көзге ялтыравык туфли: юлдан читкә атлау белән, балтырына кар тулачак.* В.Нуриев. *Рәшидә апа: «Үкчәле туфли кисәң, әйбәтрәк булыр, буйлырак күренерсең», – дигән иде.* Р.Батулла

**ТУФЛИЛЫК** *с.* **1.** 1) Туфли тегәргә яраклы яки туфли өчен җитәрлек. *Туфлилык күн*

2) Туфли сатып алырга дип билгеләнгән, шуңа җитәрлек. *Мин дә ярдәм итә алмыйм, хезмәт хакымны тулаем Кифая апага кайтарып тоттырдым. Бәлки, бер туфлилык кына калгандыр?* Р.Габделхакова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Туфли тегәргә дип билгеләнгән материал

2) Туфли сатып алырга дигән акча

**ТУФРА́ГАСТЫ** *с.* Туфракның өске катламы астындагы. *Туфрагасты катлам. Туфрагасты сулар*

**ТУФРАК** *и.* 1) Җир кабыгының үсемлекләр дөньясы тереклек итә торган өске катламы. *Йомшак туфрак аның итек табаны астында батып-батып калды.* Н.Фәттах. *Тырналган җирләре үтереп сызлау өстенә кан саркып, туфрак белән буталып, пычранып беткән.* Ф.Яруллин

2) Тузанга караганда эрерәк балчык кисәкләре. *Сугу-кыйнаулардан танымаслык хәлгә килгән мәетне һаман мәсхәрә итүдән туктамыйлар: таш, туфрак аталар, битенә төкерәләр.* Я.Шәфыйков

3) *күч.* Теге яки бу күренешләр, вакыйгалар һ.б.ш. барлыкка килгән яисә бара торган, кешеләр туып-үскән һ.б.ш. урын, мохит, җирлек. *Без анда тимер юл челтәренең үзәк урыны булган Украина туфрагында шактый гына күперләрне җимердек.* Т.Гыйззәт. *Әдәбиятка Әхсән Баянны, Хәсән Сарьянны, Суфиян Поварисовны, Ринат Хәйрине, Марат Кәбировны биргән туфрак ничек шигъри булмасын инде!* Р.Миңнуллин

4) *күч.* Як, ил; туган җир. *Ул туфрак – минем туып үскән җирем, халкым һәм безнең чынбарлык.* Н.Нәҗми. *Шуны белгәнгә күрә, үз исемемнән түгел, син яралган туфрак исеменнән сорыйм: синең алда бернинди гаебе юк аның, гафу ит син туган җиреңне.* Ә.Баян

5) *күч.* Кабер. *Тукай абыебыз әйтмешли, җәсәден туфрак алды.* Т.Галиуллин. *Кайсы ананың газиз баласы ята салкын туфрак кочагында?* Г.Гыйльманов

◊ **Туфрагы җиңел булсын** Үлгән кешегә карата теләк рәвешендә әйтелә. *Әчтә, сүрән ут яктысында җиде карчык, Коръән укып, мәрхүмәнең туфрагы җиңел булуны теләп, гүяки тагын да кемнәрнеңдер килеп керүен көтеп утыра иделәр.* Ф.Яхин. **Туфрак булу** Юкка чыгу, бетү, үлү. *– Кайтып җитәмме инде, Фәридә җаным, әллә шушында туфрак буламмы, – диде Ислам, үз-үзен кызгандырган булып.* Н.Фәттах.

*Күп татарлар, бәхет эзләп, чит җирләрдә туфрак булган.* Д.Салихов. **Туфрак итү** Юкка чыгару, бетерү, тар-мар итү. *Ханнар явын туфрак итмәсме?* М.Җәлил. *– Бер кагылуда мин теләсә кемне яңадан туфрак итә алам, – ди елан.* Р.Вәлиев

**ТУФРА́К БЕЛЕМЕ** *и.* Туфракның (*1 мәгъ.*) килеп чыгуын, төзелешен, составын, таралу үзенчәлекләрен, рациональ куллану юлларын һ.б.ш. өйрәнү белән шөгыльләнә торган фән. *Россия Авыл хуҗалыгы фәннәре академиясендә агрохимия һәм туфрак белеме буенча озак еллар дәвамында фәнни тикшеренүләр алып барыла.* Казан утлары

**ТУФРАКЛАНУ** *ф.* 1) Туфракка буялу. *Киемнәр туфраклану*

2) *махс.* Туфракка әверелү. Тау тоқымнарының өске катламы туфраклану

**Туфракланып бетү** Бик нык туфраклану

**ТУФРАКЛЫ** *с.* Туфракка буялган, пычрак; туфрак кушылган. *Ул туфраклы кулы белән уң яңагын сыпырып алган булса кирәк, бармак эзләре сузылып калган.* Г.Әпсәләмов. *Туфраклы кар йомгагы эчендә кеше белән бүре аунЫй; кем кемне нишләткәнен аңлап булмый: бүре ыркылдаганы белән кешенең көчәнгәне генә ишетелә.* Р.Батулла

**ТУФРАКСА** *и.* 1) Өйдән җылы чыкмасын өчен, түшәм өстенә салына торган туфрак белән аралаштырылган пычкы чүбе катнашмасы. *Түшәмнәренә кадәр селкенде бугай, мич кырыендагы такта арасыннан туфракса коелып, нәкъ Исхак өстенә туры килде.* Н.Әхмәдиев. *Шулай көлешә-көлешә эшләгән чагында, кечкенә энеләре Рәсим туфракса тузаны арасыннан бер пар күнитек табып алды.* Ф.Яруллин

2) Түшәмнең туфрак салынган өске, түбә ягы; чорма. *[Кешеләр] мәтрүшкә, гөлҗимеш чәчәге, тагы башка шундый чәчәкләр җыеп алып кайтып, шуны көлтәсе белән туфраксаларына менгезеп асалар.* М.Гали

**ТУФРАКЧЫ** *и.* 1) Туфракчылык белән шөгыльләнүче белгеч; туфрак белгече

2) *тар.* Туфракчылык хәрәкәте тарафдары. *Шулай итеп, дәүләтчелек мәсьәләсендә туфракчыларның һәм төрекчеләрнең уртак фикергә килү мөмкинлеге гамәлгә ашмады.* Казан утлары. *Вәлиди берүзе генә бик дөрес юлда – Россияне федерация итү, милләтләргә җирле автономия бирү (туфракчылар мәсләге) юнәлешендә тора да, татарлар һәрдаим унитарист булып чыга.* Ватаным Татарстан

**ТУФРАКЧЫЛЫК** *и.* 1) *к.* **туфрак белеме**. *Агрономия нигезен ботаника, үсемлекләр физиологиясе, генетика, биохимия, микробиология, туфракчылык кебек фәннәр тәшкил итә.* Казан утлары

2) *тар.* Идел буе төрки халыклары союзы төзү максатын куйган иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. *Мәҗлестә, Идел-Урал штатын төзү өчен, аерым бер комиссия сайлана, һәм сигез кешедән торган бу комиссиягә Г.Ибраһимов, Г.Шәрәф, И.Алкин, Г.Акчурин, С.Атнагулов, Ф.Сәйфи, С.Енгалычев, И.Хәлфин керә (болар һәммәсе дә – «туфракчылык» идеясен яклаучылар, «төркичеләр»дән бу комиссиягә берәү дә керми).* С.Максуди

**ТУЧ** *с. диал.* Бик симез, бик майлы. *Шикәр кебек шыгырдап торган туч ит.* М.Әмирханов

**ТУЧА** *и. диал.* Беренче кат бозаулый торган өченче яшьтәге сыер

**ТУЧКЫЛ** *с. диал.* Бик нык майлы; мае чыгып торган (гадәттә пешкән ит тур.)

**ТУЧКЫЛДАТУ** *ф. диал.* Туч-туч иткән тавыш чыгару; туч-туч иткән тавыш чыгарып үбү, чупылдату. *Тучкылдатып үбү*

**ТУЧКЫЛДА́У** *ф. сөйл.* 1) Туч-туч иткән тавыш чыгару; туч-туч итү. *Тучкылдама әле!*

2) Кирәгеннән артык симез булу. *Дуңгыз тучкылдап тора*

**ТУЧКЫЛЛЫ** *с. диал.* 1) *к.* **тучкыл**. *Тучкыллы ит*

2) Симез, таза кеше турында. *Тучкыллы ир*

**ТУ́Ч-ТУЧ** *иярт.* **1.** Юеш нәрсәгә йомшак кына итеп суккалаганда чыккан тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып; чупылдатып. *Туч-туч үбешү*

**ТУЧЫЛДАТУ** *ф. диал. к.* **тучкылдату**. *Иреннәрне тучылдату*

**ТУШ** I *и.* Кыш көне елга-күлләрдә боз өстенә чыккан су. *Боз өстенә су, ягъни туш чыга башлый.* А.Хәсәнов. *Кар яңгырга әйләнеп, өстенә туш чыкты да, боз түшәк кебек көпшәкләнде.* Р.Батулла

**ТУШ** II *и. рус диал. к.* **түшкә**. 1) *Минем дә бер туш ит акчасы бирәсе бар иде, җә миннән дә сорый башлар.* Г.Камал

2) *сөйл.* Гәүдә. *Тушын күтәрә алмау*

◊ **Туш чыгару** *эвф.* Яткан урынны юешләү, бәвел итү, аска сию

**ТУШ** III *и. нем.* Котлау, тәбрикләү, бүләкләү һ.б.ш. тантана вакытларында уйнала торган кыска музыкаль пьеса. *Оркестр туш уйный.* Т.Гыйззәт. *Аның рәхмәте әйтелеп бетү белән коридор ягындагы оркестр, барлык торбаларын, тәлинкәләрен, барабаннарын эшкә җигеп, бөтен дөньяны яңгыратып туш уйнады.* Н.Фәттах

**ТУШЕ** *и. фр.* 1) *муз.* Музыка коралында уйнаганда клавишларга басу ысулы

2) *спорт* Француз көрәшендә калак сөягенең җиргә тиюе. *Ул барлык көндәшләрен дә чистага, аркаларына салып, туше белән җиңде, техник яктан да, тактик яктан да барысына караганда да остарак булуын күрсәтте.* Гасырлар авазы

**ТУШЛАП** *рәв.* Тушы (II) белән. *Базарга авыллардан тушлап-тушлап ит ташый ул хәзер, шуның белән көн күрә.* Казан утлары

**ТУШЫРА́У** *ф.* 1) Боз өстенә чыгу (су тур.). *Язын күл тушырый*

2) Икенчел боз катламы хасил булу

**ТУШЬ** *и. нем.* 1) Язу-сызу, рәсем ясау өчен махсус ясалган кара яки башка төстәге сыек буяу; кытай карасы. *Аяз күк йөзе кебек зәңгәрсу кәгазьгә кара тушь белән язган хатың кулымнан төшеп китә.* Г.Рәхим. *Хат яхшы сызым кәгазенә тушь белән язылган, имзасы юк.* М.Маликова

2) Керфек буявы. *Иреннәренә, күзләренә килограммлап иннек вә тушь сылаган гүзәл кыз, Камырҗанның кочагыннан төшеп, кешечә исәнләшәсе урынга шаркылдап көлә башлады.* Х.Ибраһим. *Битен ясау аңа да проблема булмады: --- тушьлар, гельләр, ирен*

*буяулары, кара, коңгырт, куе кызыл төстәге карандашлар, тагын әллә ниләр эшкә җигелде.* Н.Көбәш

**ТУШЬЛА́У** *ф.* Тушь белән буяп чыгу, тушь салу. *Керфекләрне тушьлау*

**ТУЫМ** *и.* Билгеле бер арада туган балаларның чагыштырмача саны. *Бәби дигәнлектән, былтыр демографиядә аеруча куанычлы алга китеш сизелде: туым 8,5 процент күләмендә теркәлде.* Өмет. *Туым арта икән, димәк, авыл бетә, дип хафаланырга урын юк.* Кызыл таң

**ТУЫ́М СУЫ** *и. анат.* Карындагы баланы һәртөрле кысылу, бәрелүләрдән саклый торган сыеклык; бала суы. *Туым суы агып бету*

**ТУЫШ** *и. иск.* Туу, дөньяга килү. *Аерылу туышлардан яман икән.* И.Салахов

**ТУЮ** *ф.* 1) Ашау-эчү нәтиҗәсендә ачлыкны һәм сусынны бастыру; туклану; ашап-эчеп канәгатьләнү. *Ашап тую алдыннан гына, моңарчы кайдадыр йоклап яткан Низами килеп чыкты.* Н.Фәттах. *Көннәрдән бер көнне Мөнирҗан да мәктәптән (әбисе ни өчендер аны «мәптек» ди) кайтып ашап кына туйган иде, Фазыл килеп керде.* Н.Әхмәдиев

2) Берәр нәрсәдән канәгатьләнү. *Кама, уйнап туйган кебек, юаш кына тынычлана башлады.* Г.Әпсәләмов. *Раушания исә судан туярга уйламый да, чыркылдый-чыркылдый әтисе кулында йөзә бирә.* М.Вәлиев

3) Кирәгеннән артык еш яки күп күрү, ишетү, куллану, күп кабатлану яисә һаман бер төрле булу аркасында берәр нәрсәдән, эштән, кешедән һ.б. күңел кайту, бизү. *Наилә беренче тапкыр елый-елый, маңгаен өстәлгә бәрә-бәрә зарланды: «Туйдым бу тормыштан!»* А.Гыйләҗев. *Туйдым, бик туйдым моның сүзләреннән.* Ф.Баттал

4) Берәр сыеклык белән тулысынча туендырылу, сеңдермәс хәлгә килү. *Коры җир өстенә төшкәч, тамчы сеңә алмый мөлдерәп-тирбәлеп тора да тәгәрәп китә. Гүя җир дымнан тәмам туйган.* Ш.Галиев

5) Туклыклы матдәләрне җитәрлек туплау, тулу, тәмам өлгерү (башак, ашлык тур.). *Ашлыкларның туйган вакыты җитте, җәмәгать, рәхәтләнеп ял итәргә була.* Казан утлары

6) *күч.* Берәр нәрсәгә булган ихтыяҗ, мохтаҗлык бетү. *Бик азлары гына кире әйләнеп кайтты, алары да саулыкка туймаган ярты-йорты кеше иде...* Р.Кәрами. *Кайчакта башына мантыйкка сыймас уйлар килеп куя: берәр җирдә, җиде диңгез артында, мисал итеп торлык кына булса да, акчага туйган хатын-кыз бармы икән ул?* К.Кара

**Туеп бару** Аз-азлап, акрынлап тую. *Кечкенә генә җиңү! Үз-үзен югалта башлаган, көченә ышанычы кимегән, сабырсызлыктан гасабиланып, тормыштан туеп барган кешенең беренче җиңүе.* Ф.Яруллин

**Туеп бетү** Тәмам туяю. *Суынды шул, суыну гына түгел, тәмам килешләреңнән туеп беттем инде.* Г.Камал. *Әгәр кешегә сандугач сайравын көне-төне тыңлап торырга туры килсә, ул сандугачтан тәмам туеп бетәр иде.* Г.Рәхим

**Туеп җитү** Тую дәрәҗәсенә җитү. *Кислород аз булганга, йокы да бик туеп җитми.* З.Мәхмүди. *Морзаның сүзендә түгел, йөзендә дә ризасызлык галәмәте сизелмәвенә тәмам инангач, лоджиядән кереп китте һәм, кулына ике банан тотып, әйләнеп тә чыкты: – Бая синең тамак туеп җитмәде сыман.* Ф.Баттал

**Туеп килү** Тую алдында тору, туя башлау. *Яңа [икмәк] өлгерергә дә ерак калмас: арыш туеп килә бит инде.* И.Гази. *Аның тамагы туеп килә иде бугай.* Ф.Яхин

**Туеп киту** Билгеле бер вакыттан соң тую. *Бөтенесеннән, барысыннан туеп киткән кешенең үзе теләгәнчә яшәргә хакы бар бит инде!* М.Вәлиев. *Сизеп аның татлы тәмен алар Туеп киткән төсле булганнар.* А.Нәҗми

**Туя бару** Вакыт үткән саен күбрәк тую. *Балаларының көннән-көн үзеннән туя баруларын күреп, сизеп ята Мансур.* Г.Галиев

**Туя башлау** Туюга якынлашу. *Хастаханәдә миннән туя башлаганнар иде, курортка барып булса, алар – миннән, мин алардан бераз ял итәр идем.* Ф.Яруллин. *Ипигә яңа гына туя башлаган еллар.* Р.Миңнуллин

**Туя төшү** Элеккегә караганда ныграк тую. *Ат куа башлагач, тамак туя төште.* Ә.Моталлапов

**ТУ́Я** *и. гр.* Кипарислар семьялыгыннан тәңкәсыман ылыслы мәңгеяшел вак агач яки куак; савыр. *Чинар, платан агачларыннан, куаклардан иртәнге салкынча һавага искиткеч затлы куе ис – туя куаклары исе таралган ---.* М.Мәһдиев. *Су буйларында миләш, шомырт, балан, алмагач, туя агачлары, артыш куаклары күзне иркәли.* Г.Габидуллина

**ТУЯ́** *рәв.* Бик күп; туйганчы, күңел булганчы. *Берәүләр икмәк белән мал-туар симертә, безнең ишегә туя ашарга да юк.* А.Гыйләҗев. *Дөньяның ачысын да, төчесен дә туя күргән ике әби, хәзер инде хикәятләрен йотлыгып тыңлаучы унбер яшьлек кызыкайның барлыгын да онытып, байтак серләшеләр әле.* А.Юнысова

**ТУЯ́Р-ТУЙМАС** *рәв.* Җитәрлек дәрәҗәдә туймыйча; туеп бетәр-бетмәс. *Көндез укый, кич эшли, төннәр буе дәрес әзерләп, туяр-туймас йокы белән мәктәпкә китә.* Сөембикә

**ТҮ** *и. диал.* **1.** Төелгән тары ярмасы

**2.** *с. мәгъ.* Шул ярма оныннан пешерелгән. *Тү белене, тү коймагы – минә аларның сыйлары.* Г.Әпсәләмов

**ТҮБӘ** I *и.* **1.** 1) Бинаны, корылманы өске яктан ябып, аны кар-яңгырдан саклый торган каплама. *Кая карама – салам түбә, җимерек каралты-кура, тал чыбыгыннан үреп балчык белән катырган ихата.* М.Хәсәнов. *Карт, тәмәкесен суыра-суыра, --- күрше йортларның карлы түбәләрен күздән кичерде.* С.Шәмси

2) Башның иң өске өлеше. *Көндезге кояш та баш түбәсен кыздыра, тирләрне дә юып төшерәсе килә.* Ф.Галиев. *Урта буйлы бу картның баш түбәсе самавыр җиседәй ялтырый, ә чигәләрендә һәм түбәсе артында яңа яуган кар сыман чәчләре дулашып тора.* Б.Камалов

3) Нәрсәнең дә булса өске өлеше, башы. *Кепканың козырёгы тырпайган, сигезгә бүленгән түбәсендә --- төймәсе дә бар.* А.Гыйләҗев. *Кунакларның берсе түбәсе очлайган, маңгаенда зур кызыл йолдызлы шлем кигән.* М.Мәһдиев

4) Берәр биек нәрсәнең (мәс., тау, агач һ.б.ш.ның) очлаеп торган өлеше, башы. *Тау түбәсе – ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора.* Ә.Еники. *--- күпме генә менсәң дә, ул кыяның түбәсенә менеп җитә алмаячагыңны аңларга кирәк ---.* И.Юзеев

5) Кечерәк калкулык, калку урын, кашлак. *Тигез җирдән түбә җир күп.* Мәкаль. *Урманны чыгып, Юкә борыны дип йөртелә торган түбәгә күтәрелгәч, Сәфәргалинең күз алдында авыл --- уч төбендәге кебек булып ачылып калды.* Ф.Хөсни

6) *мат.* Ике туры сызыкның почмак ясап кисешкән ноктасы. *[Лобачевский], Кейда, Ригель һәм Сириус йолдызларын өчпочмакның түбәләре итеп алып, гаять зур космик өчпочмак төзи.* Җ.Тәрҗеманов. *Өчпочмакның А түбәсеннән AD медианасын үткәрәбез һәм аның өстендә М ноктасын алабыз.* Югары математика нигезләре

7) *диал.* Чорма. *Соңыннан тыгызлап тутыргач, [казылыкны] өй түбәсенә элеп куялар да өлгереп җиткәнен көтәләр.* Н.Әхмәдиев. *Түбә башыңны былтырлары гына яптырган идең бит әле?* Х.Ибраһимов

8) *сир.* Түшәм

9) Кемнең яки нәрсәнең баш өсте, турысы. *Үз түбәсендә кара болытның куерганын, яшен ялкыннары уйнавын күргәч, татарның авыр йокылы катламы да сискәнде.* Г.Ибраһимов

10) Кыяклы үсемлекләрнең сабак очында озынча булып укмашып утырган орлыклар теземе, башак. *Түбә туклыгы*

11) *күч.* Иң түбән нокта, иң түбән урын. *Мин, бер тәгәрәп, бер торып, чокырның түбәсенә хәтле төш[тем].* Ш.Камал

12) *күч.* Яшәү урыны. *Кыз бала гомер буе ата-ана түбәсе астында яшәми.* М.Хәсәнов. *Ә болай баш өстендә үз түбәсе булмаган килеш эт тибенгесендә йөреп, ул гомумән кешелектән дә чыгарга мөмкин.* Ф.Садриев. *Киресенчә, мондагыларның баш очында түбә бар, бөтенләй үз куышы булмаганнарны кайгыртырга кирәк башта, диләр.* М.Маликова

13) *күч.* Җинаятьчел даирәдә аерым бер төркемнең, билгеле бер сумманы даими түләп бару бәрабәренә, физик яки юридик затларны ихтыяри яки мәҗбүри саклавы, яклавы; шуның белән шөгыльләнүче затлар. *Бүген җыен вак-төяк ышпана бәйләнми, чөнки без яллаган «түбә» Казанны дер селкетеп тора.* Н.Гыйматдинова. *Хәзер төркемнәр «бизнес» белән шөгыльләнә, күбесенең үз эчендә уртак кибетләре бар, --- кемдер башкаларга «түбә» ясый ---.* Х.Ширмән

**2.** *с. мәгъ.* Калкуланып торган, калку. *Аның кодрәте белән кырларда карлар ашыгып эри, түбә җирләр көннән-көн ачыла бара ---.* Ә.Еники. *Бу түбә урын иде.* Х.Камалов

◊ **Түбә асты** Ми, зиһен, акыл. *Бармы синең түбә астыңда берәр шомың?* Ф.Хөсни. **Түбә астына алу** Кемне дә булса яклау, саклау, химая итү. *Зур гына кибет ачылды. «Ачылган – ачылган. Бик яхшы. Хәзер аны үз түбәбез астына алырга кирәк», – дип уйлады «Таулар» төркеме лидерлары.* Ә.Сафиуллин. **Түбә астына керү** 1) Төзелеп бетмәгән бинаның түбәсе ябылу. *– Аллага шөкер, түбә астына керде, калганы әкренләп эшләнер, – диде Габдрахман карт.* Яңарыш; 2) Кемнең дә булса яклавына, саклавына сыену. *Әгәр [кибет хуҗалары] «түбә астына» керергә теләмәсәләр, ягъни акча түләп торудан баш тартсалар, ни буласы билгеле: я анда янгын чыга, я шартлый, я хуҗасы физик көчләүгә тартыла.* Ә.Сафиуллин. **Түбә башына утырту** *к.* **төп башына утырту**. **Түбәгә менеп төшү** *гади с.* 1) Башына сугу. *Ачуымны китермә! Түбәңә берне менеп төшәрмен.* Г.Насрый; 2) Ачуланып, тиргәп алу. **Түбәгә менү** Артык узынып китү, башкалар белән санлашмау. **Түбәгә тукмак кундыру** *к.* **түбәгә менеп төшү**. *– Кадереңне белсәләр ярый, – дип сүзгә кушылды Плеханов, – югыйсә шулай килеп чыга: син аларга ярдәм итәсең, алар соңыннан синең түбәңә тукмак кундыралар.* Г.Әпсәләмов. **Түбәдән кереп аягыннан чыга алырлык (торган)** Үткен, чая. *Иптәшем түбәңнән кереп аягыңнан чыга алырлык бик шома кыз иде. Шулхәтле үгетләп ялварынды, сабырым төкәнеп, ризалык бирергә мәҗбүр булдым.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Түбә кыйшаю** Акылга җиңеләю, акылдан язу, юләрләнү. *– Мин сиңа рәнҗер идем, Ирек, әмма... – Ул нәрсәдер уйлап торды да өстәп куйды: – Синең әзрәк түбәң кыйшая башламадымы икән? Шуңа күрә рәнҗемим.* Ф.Садриев. **Түбәсе күк белән япкан** Хәерче, йортсыз-җирсез (кеше). **Түбәсе күккә ашу** *к.* **түбәсе күккә тию**. **Түбәсе күккә тию** 1) Бик биек булу (биналар, таулар тур.). *Без заводлар, йортлар торгызабыз, Түбәләре күккә тиярлек.* Ә.Ерикәй; 2) Бик нык шатлану, куану, канәгать булу. *Беләсе иде, аларның беренче мәхәббәт җимеше кем булыр икән: малаймы, кызмы? --- Малай булса, Мөниренең түбәсе күккә тиясен белә.* Н.Әхмәдиев. *Гадилнең: «Иркенләп утырыйк әле, Яңа елны бер көн алдан каршы алыйк», – дигән сүзләрен ишеткәч, Тәбриянең түбәсе күккә тиде...* М.Маликова. **Түбәсенә карасаң, түбәтәй төшәрлек** Биек. *Менә шунда район башлыгының ахириеме, туганымы, атасы җиренә килгән кебек, урман кырыеннан эчкә кереп, наратларны, юкә һәм имәннәрне кистереп, түбәсенә карасаң түбәтәй төшәрлек хан сарае салдырып ята икән.* З.Фәйзи. **Түбәсенә күсәк төшү** Кылган гамәлләр өчен берәр җәзага тартылу. *Зөфәр Шәрипович иң әүвәле теге кешенең үлүен теләде. Ул чакта Батталовка котылмак юк, Арслановның да түбәсенә ару гына күсәк төшәчәк.* Ф.Садриев. **Түбәсенә суккан (бәргән) төсле (кебек)** Көтелмәгән хәбәрдән югалып калу. *Шул сүз тегенең түбәсенә суккан төсле булды, тыгылды, сүзен әйтә алмый башлады.* М.Гали. *Зәйтүнәнең бу сүзләре Әухәдинең түбәсенә тимер чүкеч белән бәргән төсле булды. Ул агарынды, ирennәре калтыранды.* К.Тинчурин. **Түбәсеннән ашкан** Җитеп арткан, кирәгеннән артык, күп. *Үзеңә кирәкле запас частьларны миннән таптырыргамы әллә исәбең? Минем синнән башка да мәшәкатьләрем түбәмнән ашкан.* Г.Тавлин. *Кларaның шатлыгы түбәсеннән ашты.* А.Хәсәнов. **Түбәсеннән тотыру** Әйберне нәрсәгә дә булса тәмам

тутырганчы салу, түбәләмә итеп тутыру. *Иван Иванович зур гына җамаякны түбәсеннән тутырып, уртасына көнбагыш мае салып, тары боткасы бирде.* И.Салахов. **Түбәсе салам белән капланган** *к.* **түбәсе салам белән ябылган**. **Түбәсе салам белән ябылган** «Сүзнең ни турында барганын, эшнең нәрсәдә икәнен аңлый» дигән мәгънәдә (еш кына чит милләт кешеләре тур.). *[Сергей] безнеңчә дә яхшы сукалый: түбәсе карабодай саламы белән япкан, димәк...* Ш.Бикчурин. **Түбәсе түшәмгә ашу** *к.* **түбәсе күккә тию**. **Түбәсе түшәмгә тию** *к.* **түбәсе күккә тию**. *Бер-ике сәгать азапланганнан соң, --- магнитофон, ниһаять, әйбәт кенә эшләп киткән иде. Моны күреп торган Якуп Сәйфинең түбәсе түшәмгә тия язды.* Э.Касыймов. **Түбәсе тишек** *к.* **түбәсе салам белән ябылган**. *Тик, Әнисә кызым, әйткәнем булсын, кеше-карага күрсәтмичә генә эч инде. Дус бар, дошман бар, дигәндәй. Күршеңнең түбәсе тишек түгелме?* Г.Әпсәләмов. *Янәшәдәгесе --- кызның йөз ямаулы сырма җиңеннән тартып: – Апаем, күп сөйләшмә инде, берәрсенең түбәсе тишек булуы бар, – диде, ярым пышылдап.* А.Әхмәтгалиева. **Түбәсе түшәмгә житү** Һәр яктан да камил, җитеш булу. *Шабанов та һәм редактор да, «Күңелле балалар»ның түбәсе түшәмгә җиткән инде дип, үзләрен тынычландыру юлына бас[мыйча], --- китапка кергән әсәрләрнең кимчелекле якларын төзәтү өстендә күп кенә эшләргә тиешләр.* Л.Җәләй. **Түбә чәче үрә тору** Бик нык курку яки гаҗәпләнү. *Менә танк коры елганы да үтеп чыкты. Тавышыннан җир селкенә. Түбә чәчләре үрә тора.* Ф.Шәфигуллин. *– Аның белән бәйләнсәң! Кайтып төшү белән милициягә йөгергән! – Нәрсә, нәрсә? – Чуртанның түбә чәчләре үрә торды.* М.Насыйбуллин

**ТҮБӘ** II *и. диал.* Авылның бер өлеше, очы

**ТҮБӘ́ КҮЗЕ** *и. зоол.* Кайбер хайваннарның (мәс., кәлтәләрнең) баш түбәсендәге өченче күзе; *русчасы*: **темянной глаз**

**ТҮБӘЛӘМӘ** *рәв.* 1) Бик тулы тутырып, түбәсенә, кырыйларына кадәр өеп, тутырып. --- *бу доктор аның авызындагы йозакны алды, түбәләмә тулган капчыкны чишеп җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Гаҗилә ул күтәреп кайтырга тиешле алсу венгр алмалары белән түбәләмә тулган --- чиләген урындыклар арасындагы керү-чыгу юлына куеп калдырган иде.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Күпләп, тыгызлап тутырылган; шыгрым. *Казан вокзалы бүген дә түбәләмә туп-тулы иде.* К.Нәҗми

**ТҮБӘЛӘНҮ** *ф.* Кабарып күтәрелү, түбә рәвешен алу. *Кайнаганда, сөт түбәләнеп менә.* Азат хатын

**ТҮБӘЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Тәнне авырттырырлык итеп күп тапкырлар сугу; кыйнау, тукмау. *Нервыларының соңгы чиккәчә киерелгән шундый чагында, егылганны түбәләгәндәй, Гайсә шалтыратты ---.* Ф.Садриев. *Бүтәннәр дә түбәли инде бу егет сәләмәсен.* Р.Кәрами. *Берәүләр егылганны түбәләргә кушалар, икенчеләре, аякка бастыру мәслихәт, дигән фикердә торалар.* Ф.Баттал

2) Әрләү, битәрләү; орышу, тиргәү. *Бәхетсезне, көчсезне түбәләү, рәнҗетү – үз намусыңны аяк астына салып таптауга тиң түбәнлек.* М.Хәсәнов. *Егылганны түбәләү нигә кирәк? Мин карт кеше, авыру кеше, авыру кеше белән булышу нигә кирәк?* Р.Батулла

**Түбәләп ташлау** Тиз арада, ачу белән, кызып китеп түбәләү. *Бүз җегет заманымда тукалның җылкысын урлап бер тотылдым. Аркамны ярганчы кыйнадылар. Шуннан бирле һичбер адәм кул тидергәне юк иде... Бүген яман бер кимпер ил алдында түбәләп ташлады...* Г.Ибраһимов

**Түбәли башлау** Түбәләргә тотыну. *Күземә яшь килде, янымдагы бүз балаларга: «Картны куя бирегез, китсен, күңелем бозылды», – дидем. Берәүсе телемне алмады, яңадан түбәли башлады. Карт аягыма егылды ---.* Г.Ибраһимов

**Түбәли бирү** Түбәләүне дәвам итү. *Кемгә зарланганымны үзем дә белмичә: – Ыч... ычкындырдык!.. Шундаен таймeньны ычкындырдык!.. – дип, мин һаман җирне түбәли бирдем.* В.Астафьев

**ТҮБӘЛӘШ** *и. сөйл.* Йодрык сугышы, орыш. *Түбәләштә йодрыкның зуррак һәм ныграк булганы яхшы.* И.Гази

**ТҮБӘЛӘШҮ** *ф. сөйл.* 1) Сугышу, кыйнашу. *Абзагыз кайчандыр бандитлар белән түбәләшкән, кызлар сөйгән шәһәрдә йөри.* И.Гази. *Сахипгәрәй илә Дәүләтгәрәй түбәләшеп [һәлак] булдылар.* Шура

2) Гаугалашу, даулашу, җәнҗал куптару. *Әтиең белән түбәләшергә дә җыенып өлгердеңмени әле?* Ф.Бурнаш

**Түбәләшә башлау** Түбәләшергә тотыну. *Арттан килгәне: «Һәр ни булса, синең бәхетең», – дип тарткалаша торгач, гауга зурга китте, йодрыкка-йодрык түбәләшә башладылар.* К.Насыйри

**Түбәләшеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә түбәләшү

**ТҮБӘЛДӘК** *и. диал.* 1) Шалаш, куыш башына кидерелә торган очлы кап, капчык

2) Конус

**ТҮБӘЛЕК** *и.* **1.** 1) *к.* **түбә** I (*5 мәгъ.*). *Авылдан шактый арырак, түбәлектә, ерактан уенчык тартма кебек кенә булып трактор вагоны --- күренә.* Ф.Хөсни. *Иванны ике атлы казак түбәлек артына алып китте.* Г.Минский

2) Түбә ясарга дип әзерләнгән материал. *Капка, түбәлек, тәрәзәләр – барысы кайтарылган.* Авыл офыклары

**2.** *с. мәгъ.* Түбә өчен яраклы, (бер) түбәгә җитәрлек. *Түбәлек такталарыңны әзерләп куй.* Х.Вахит. *Акчалы кешеләр күбәеп килә, кемдер бура ала, кемдер түбәлек шифер кайтарта.* Ф.Яруллин

**ТҮБӘН** *с.* **1.** 1) Җиргә яки берәр җирлек өстенә якын

2) *сөйл.* Аскы, астагы. *Алар этажында беренче курс кызлары яши, югары курслар түбәнрәк бүлмәләрдә торалар иде.* Х.Ширмән. *Мин ул чакта Вәли байның теге өлкән урамдагы зур таш пулатының түбән катында – җир астында тора идем.* Р.Гайфуллина

3) *к.* **түбәнге** (*1 мәгъ.*). *[Миңнулла], Якубны өйдә очрата алмагач, --- түбән очка таба төшә башлады.* И.Гази. *Гөлгенә белән иңне иңгә терәп түбән очтан менгәнне Наиләсе күрсә ни уйламас.* А.Гыйләҗев

4) Уйсу; иңкү. *Шәһәр ягындагы тау өсте бакчасыннан караганда, каршыда-*

*гы түбән якта искиткеч матур иксез-чиксез бер күренеш ачыла.* Ш.Камал

5) Елганың агымына карата астарак урнашкан. *Хан аны [Сарбай ханны] колач җәеп каршы алды, Иделнең түбән якларын сакларга кушты.* М.Хәбибуллин. *Сәгатьтән карап белмәдем, ә бу турыдан ярты чакрымнар тирәсе түбәндәрәк булган комлы кичүгә көтүнең туплауга төшүен күреп чамаладым.* Ә.Гаффар

6) Сәләте, белеме, акыл, эш дәрәҗәсе, яше һ.б.ш. сыйфатлары ягыннан кемнән булса да калыша торган; кайтыш, кечерәк. *Телеграммасына караганда, түбән белемле дип булмый моны.* Ш.Рәкыйпов. *Ә инде ирнең хатыны дөньяга иң әүвәл үзен күрсәтеп барса, ул ирнең дәрәҗәсе түбән дигәнне аңлатыр.* Ә.Гаффар

7) Сыйнфый яктан хокуклары һәм матди мөмкинлекләре чикләнгән. *Бу боерык --- төптән уйлап өйрәнелсен һәм түбән чиннарга һәрьяклап аңлатып бирелсен.* Ш.Рәкыйпов. *Ә шул вакытта түбән катлау балаларының берничә буынына югары белем алу ишекләрен бөтенләй ябарга туры киләчәк.* Ж.Тәрҗеманов

8) *лингв.* Урам теленә хас булган. *Түбән стильдә язу*

9) *сөйл.* Намуссыз, оятсыз, әдәпсез. *Шулай ук син мине шундый бозык, түбән кеше дип уйладыңмы, Хәмит.* Р.Ишморат. *Андыйлар бөтенесе шулай түбән җанлы бит. Баер өчен, зур кеше булырга да кирәкми.* З.Фәйзуллин

10) Тиешле югарылыкта булмаган, үсеш алмаган. *Мичурин иске Россиядә бакчачылык эше нинди түбән, кызганыч, башлангыч хәлдә булуын күрсәтә.* А.Бахарев, П.Яковлев

11) Кайбер вәкиллекле органнарның киңрәк составтагы, азрак вәкаләтле өлешен тәшкил иткән. *Узган атнада Япония парламентының түбән палатасына сайлауларда либерал-демократлар партиясе җиңеп чыкты.* Шәһри Казан

12) *күч.* Газаплы, мәшәкатьле; тар. *Гали рухың бу түбән дөньяны һич тиңсенмәде.* М.Гафури

13) *күч.* Бозык, азгын; мәгънәви кыйммәте аз булган. *Бу Кояш, бу Көн, бу Тормыш каршында синең ялган хыяллар, түбән хисләр белән сугарылган гомер кисәгең бернигә дә тормый...* Г.Гыйльманов. *Кайда түбән хисләр, ниятләр, бозыклык, кайда нәфрәт, сугышлар, ярсулык, дошманлык – анда һәлакәтләр, аварияләр, катастрофалар.* Әдипләр

14) *күч.* Кимсетүле, түбәнсетүле. *– Күзе төшкән бер иргә сылана торган хатын икән ләбаса ул! – дигән түбән караш туу бик күңелле түгел ич.* Ш.Камал // Хурлыклы, мәсхәрәле. *Мин аңа хатынымны яманламас идем, чөнки хатын яманлаудан да мәгънәсез, түбән эш юк.* Ә.Еники. *Бу уйлар --- нигездә улына юнәлдерелгән: хурлыклы, түбән юлга баскан улына карата әрнүле мөнәсәбәт ап-ачык булып ярылып ята ---.* Х.Сарьян

15) *күч.* Сыйфаты ягыннан башкалардан кайтыш. *Яңа программа исә түбән сортлы агачны да кирәкле юнәлештә файдалану мөмкинлеге бирәчәк.* Ватаным Татарстан

16) *күч.* Бәяләнүе, кыйммәте аз булган; микъдары, көче, дәрәҗәсе һ.б. сыйфатлары аз саннар белән бәяләнә торган. *Ул көнне Хатим Миннебаеч --- нишләптер группаның иң чибәр кызына да түбән билге куеп чыгарды.* М.Галиев. *Кар астында мондый урман туфрагының температурасы еш кына 0 градус тирәсендә була, гадәттә ул 1–2 градустан түбән төшми.* Ботаника

17) *күч.* Арзан, очсыз. *Кешегә караганда түбән бәягә алучы булгач, җәмәгать риза була.* М.Гали. *Ризык шәһәр кафесындагыдан тәмлерәк, бәясе берничә мәртәбә түбәнрәк.* Т.Әйди

18) *күч.* Интеллектуаль яктан тиешле дәрәҗәдә булмаган. *Әтиеңне дә юкка гына үзеңнән түбән белгеч итеп исәплисең.* Р.Ишморат

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Җиргә якын, түбәнтен, астан

2) Аска, аска таба. *Кояш та яхшы ук түбән төшкәнен --- уйлап, --- алга таба киттем.* М.Гафури. *Бераз баруга юл түбән төшә башлады.* Ф.Яруллин. *Мөршидә оялып башын түбән ия.* Р.Ишморат. *Капчык эченнән язу килеп чыга: «Тот капчыгыңны, авызын түбән таба куеп...»* И.Юзеев

3) Язма текстның алдагы өлешендә, алга таба, киләчәктә. *Түбәндә, тулаем сумманы чыгарып, «җәмгысы – ике мең тәңкә» дип язылган иде.* А.Тимергалин. *Түбәндә сүз алып барылачак урысча текстларны иң беренче булып Н.Н. Ардашев үзенең --- мәкаләсендә китергән.* С.Алишев. *Түбәндә ул хатның күчермәсен китерәм.* С.Ибраһимова

4) Канәгатьләндермәслек дәрәҗәдә, начар. *Пани, сез минем хакта алай түбән уйламагыз ---.* М.Хуҗин

5) Белем дәрәҗәсе ягыннан артта. *Кадрларның күпчелеге музыка һәм вокаль культуралары ягыннан бик түбән торалар.* М.Җәлил. *Яшьләре минем белән тиң --- булып та, укулары түбән булган малайлар минем белән якын дус булып тору юлларын эзли башладылар.* М.Гафури // Сәләте, акыл, эш дәрәҗәсе, яше һ.б.ш. сыйфатлары башкаларныкыннан ким // Аз, бәясен ким итеп, арзан итеп. *З.Рәмиев [шагыйрьләргә] --- гонорарны да түбән түләми.* З.Бәшири. *Базарда итекнең кыйммәте бик түбән төш[те].* Г.Тукай

6) Артта, элек. *Гаиләм, җылы почмагым, тыныч тормышым, яшәү дәверендә барлыкка килгән элементләрем – барысы да түбәндә калды.* М.Юныс

**3.** *и. мәгъ.* 1) Ас, аскы урын. *Өч көн үткәч кенә, аның гәүдәсе кайдадыр Дим түбәнендә килеп чыккан.* М.Кәрим. *Түбәнгә төшү*

2) Сәләте, акыл, эш дәрәҗәсе, яше һ.б.ш. сыйфатлары ягыннан кемнән булса да калыша торган кеше. *[Аделя:] Мин ничә еллар инде үземнән түбәнгә килеп тап булырмын дип куркам.* М.Мәһдиев. *Ник без үзебездән түбәннәрдән гыйбрәт алмыйбыз икән дә гел-гел югарыга үрләгәннәргә карыйбыз икән?!* А.Гыйләҗев

3) Ишеккә якынрак булган урын; *киресе:* **түр**. *Син, зинһар инде, шунда рәтләп кунакларны карап утырта күр. Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен.* Г.Камал

**4.** *хәб. функ.* 1) Төптә, аста булуны белдерә. *Иртәдән бирле карлыгачлар да түбән очалар.* Т.Гыйззәт. *Кояш төшә баю уңаена, Түбән инде кояш, бик түбән...* Ф.Гыйззәтуллина

2) Интенсивлыгы, дәрәҗәсе һ.б.ш. белән кимрәк, арттарак булуны белдерә. *Гөлнур --- каршы төшеп: – Отчётта һәр савымчыга уникешәр сыер дип язылган. Ә чынында нәрсә?.. Шулай алдашуыбызга да карамастан, күрсәткечләребез гаять түбән.* М.Хәсәнов. *[Марат] Училищеда --- укыту-өйрәтү системасы түбән.* З.Фәйзуллин

◊ **Түбән авыл этләре (көчеге) өрү** *гади с.* Ашыйсы килү, ачыгу. **Түбән җанлы** Тәрбиясез, әхлаксыз. *– Кыланышларын күрсәң, бер ач мескен диярсең... – Андыйлар бөтенесе шулай түбән җанлы бит.* З.Фәйзуллин. **Түбән китү** *к.* **түбән тәгәрәү**. *--- электән саклык ашлык-фәлән дә булмаганга күрә, безнең тормышның матди ягы да күзгә күренерлек түбән китте.* М.Гафури. **Түбәннән (башлап) югарыгача (югарыга кадәр)** Системаның барлык буыннарында да; коллективның гади әгъзаларыннан башлап югары дәрәҗәдәгеләренә кадәр. *Армияне идарә итү иң түбәннән башлап иң югарыга кадәр [булсын].* Ф.Әмирхан. **Түбәннән күтәрелү** Иң түбәнге катлаудан, әкренләп рухи һәм рәсми яктан зур дәрәҗәгә ирешү. *Без түбәннән – тормышның төбеннән күтәрелдек.* Г.Ибраһимов. *Айсылу – авыл советларында һәм колхоз идарәләрендә эшләүче меңләгән хатын-кызлар вәкиленнән берсе, аларның да иң түбәннән күтәрелгәне.* Г.Бәширов. **Түбән оч этләре (көчеге) өрү** *к.* **түбән авыл этләре (көчеге) өрү**. *Нәрсә ашарга? Түбән оч этләре бик каты өрә башладымыни?* И.Гази. **Түбән тәгәрәү** Белем дәрәҗәсе, кешелек сыйфатлары ягыннан башкалардан артка калу, булган дәрәҗәне югалту. *Ә күп, яхшы эшләгән кеше түбән тәгәри алмый.* А.Мифтахетдинов. *Юк инде! Зәринә үз кадерен үзе белә торганнардан! Бервакытта да ул дәрәҗәдә үк түбән тәгәрәмәс...* Г.Әдһәм. **Түбән төшү** *к.* **түбән тәгәрәү**. *– Моңарчы сезгә хөрмәтем зур иде. Хәзер... – Мин сезнең каршыда түбән төштеммени?* Г.Әпсәләмов. *Гөлкәй Салихҗановна, алай түбән төшмәгез, совет хатын-кызларына тиешле булганча, үзегезне горур тотыгыз.* Х.Ширмән

**ТҮБӘНӘЙТҮ** *ф.* 1) Түбәнгәрәк, аскарак төшерү, җир өслегенә якынайту. *Үпкәлә син соры болытларга: Түбәнәйтте алар күгемне. Тәбәнәк тә, тар да хәзер дөнья – Сыйдыралмыйм анда күңелне.* Р.Вәлиев

2) Көчен, интенсивлыгын, тизлеген һ.б.ш. билгеләрен киметү, азайту. *--- эрозия процесслары --- туфрактагы микроорганизмнарның кимүен көчәйтәләр, шуның белән туфракларның микробиологик эшчәнлеген һәм аларның уңдырышын бик нык түбәнәйтәләр.* Күпьеллык үләннәр. *Болытлы көндә --- температураны түбәнәйтергә кирәк, юкса болытлы көндә температура югары булса, үсемлекләр сулыш алу өчен туклыклы матдәләрне күп тоталар.* Яшелчәчелек

3) *күч.* Кимсетү, кеше алдында хурлыклы хәлгә кую, абруен төшерү, кешелек дәрәҗәсенә тию, түбәнсетү. *Эшсезлек сине коллективтан аера, түбәнәйтеп, кимсетеп күрсәтә.* М.Юныс

4) *күч.* Әһәмиятен, дәрәҗәсен башкалардан кимрәк итеп күрсәтү. *Балачакта һәркайсыбыз – кечкенә бер язучы. «Кечкенә» дип әйтү бу очракта һич кенә дә кечерәйтеп яисә түбәнәйтеп әйтү түгел.* Р.Низами. *Әмма беренче курслар алдында үземне түбәнәйтәсем килмәде ---.* Ф.Яхин

**Түбәнәйтә бару** Торган саен ныграк түбәнәйтү. *Һәр көнне суның температурасын берәр градуска түбәнәйтә барыгыз.* Шәһри Казан

**Түбәнәйтә башлау** Түбәнәйтергә тотыну

**Түбәнәйтә бирү** Бернигә карамый түбәнәйтү. *Төнге караңгылыкта прожектор яктысы самолётка таба үрмәләгәндә, очыш биеклеген түбәнәйтә биреп, бомбага тотасы урынга төгәл килә дә, бомба люгы ачылганда, туктап калгандай алым куллана.* Ф.Вахитов

**Түбәнәйтә төшү** Бераз түбәнәйтү; тагын да түбәнәйтү. *Аннары, тәрәзә аша урамга карап, бераз тыныч торганнан соң, тавышын түбәнәйтә төшеп өстәде ---.* Марс Шабаев

**Түбәнәйтеп җибәрү** Бераз түбәнәйтү. *Өстәвенә, автор бу героен ясалма хәлләргә куеп та түбәнәйтеп җибәрә.* Казан утлары

**Түбәнәйтеп калу** Түбәнәйтергә өлгерү; түбәнәйтү белән чикләнү. *Болар барысы да, тыңлаучыларның музыкаль һәм эстетик зәвыгын түбәнәйтеп кенә калмыйча, --- музыка сәнгате алдында торган изге бурычларның һәм, ниһаять, аның миссиясенең дә әһәмиятен югалта.* М.Макаров

**Түбәнәйтеп килү** Алдан ук, эзлекле рәвештә түбәнәйтү

**Түбәнәйтеп кую** Кисәк түбәнәйтү. *Ул тиз арада гарәп илләрендә нефть чыгаруны арттыруга ирешеп бәяләрне элеккедән дә түбәнәйтеп куячак, һәм без ислам дөньясындагы соңгы дусны да, озак еллар файда китерердәй контрактларны да югалтачакбыз.* Безнең гәҗит

**Түбәнәйтеп тору** Даими рәвештә, әледән-әле яки вакытлыча түбәнәйтү. *Эш хаклары да иң түбән дәрәҗәгә төште. Эшчеләр «үзләре теләп» таралып бетсен өчен, юри дә түбәнәйтеп торалар иде шикелле анысын...* З.Мифтахов

**ТҮБӘНӘЮ** *ф.* 1) Югарыдан аска таба юнәлү, югарылыгын югалту; түбәнгә төшү, җир өстенә якынаю. *Буй үскән саен, күк түбәнәя. Яшь арткан саен, яшь кызлар күбәя.* Р.Зәйдулла. *Әңгәмә түгәрәкләнгәндә, кояш түбәнәеп, ешкынлык арасына сизелер-сизелмәс кенә караңгылык иңә башлаган иде.* З.Фәйзи

2) Берәр халәтне күрсәтә торган билгеләр, сыйфатлар кимү, нәрсәнеңдер интенсивлыгы бетү. *Соңгы 20 ел эчендә кешенең ис һәм тәмгә сизгерлеге бик нык түбәнәйгән.* Н.Измайлова. *Ләкин җитәрлек кадәр югары температураларда тиз бара торган реакцияләр, температура түбәнәйгәндә, кинәт әкренәяләр яки бөтенләй туктап калалар.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

3) *күч.* Хурлыклы хәлгә калу, кимсетелү, дәрәҗәсе төшү. *Нинди авыр елларда да, башка күпләр түбәнәйгәндә, гаиләләре фәкыйрьлек-мескенлеккә дучар булганда, ул үзенең бу оясын саклады гына түгел, ныгытты, беректерде.* М.Маликова

**Түбәнәеп алу** Азга гына, вакытлыча түбәнәю. *--- статуслары вакытлыча*

*түбәнәеп алган Иске Ашыт, Шурабаш мәктәпләренең торышы, сакланышы Яңа Кишетнекеннән югарырак бәя алдылар.* Арча хәбәрләре

**Түбәнәеп бару** Әкренләп түбәнәю. *Керсез карны алсуландырып, әкрен генә түбәнәеп барган кояш та нәкъ шушындый булгандыр, бер ягы кителеп, югарып калган сары йөзле карт ай да ---, кояш баеганны көтмичә, күккә менеп киткәндер...* М.Маликова

**Түбәнәеп бетү** Нык түбәнәю, тәмам түбәнәю. *Чыгыш ясаучының баштагы көр тавышы йомшара, бөтенләй түбәнәеп бетә.* Ф.Садриев

**Түбәнәеп калу** Берәр тәэсирдән түбәнәйгән хәлгә килү. *Урләрем... Нигә хәлләреңне белмәдем? Кинәт үзем түбәнәеп калдым. Кайда минем утлы төннәрем?..* И.Юзеев. *Күк йөзен иртәдән бирле соры болыт баскан, түбәнәеп калган гөмбәз җанны изеп тора сыман.* Р.Зәйдулла

**Түбәнәеп килү** Әкренләп түбәнәю. *Бөтен тирә-ягы ерактан ук сөзәк кенә түбәнәеп килгән шау чәчәкле тигез ялан.* Ә.Еники. *Кояш кызарып, түбәнәеп килә, юллар тузан томанына уралган, күңел төшенке иде.* М.Маликова

**Түбәнәеп китү** Кисәк, ирексездән түбәнәю. *Дөрес, кайчакта өлгерешнең бераз түбәнәеп киткән мизгелләре булгалады.* Р.Вәлиев. *Кан басымы шунда ук 30 берәмлеккә түбәнәеп китәчәк.* Кызыл таң

**Түбәнәя бару** Торган саен ныграк түбәнәю. *Аннары [аэроплан], түбәнәйгәннән-түбәнәя барып, ниһаять, ипподром эчендә күздән югалды...* М.Хәсәнов. *Очкыч, әкрен генә түбәнәйгәннән-түбәнәя барып, кыеклап суга кереп тә китте.* Р.Сәгъди

**Түбәнәя башлау** Түбәнәергә тотыну. *Очкыч сагаеп кына түбәнәя башлады һәм тиздән соргылт томан эченә чумды.* М.Юныс. *Көпшәдән гаять зур тизлектә очып чыккан снаряд 90 секунд эчендә 40 километр биеклеккә күтәрелә, аннан инде түбәнәя башлый ---.* Кызыклар дөньясында

**Түбәнәя килү** Эзлекле рәвештә, әкренләп түбәнәю. *Ике яклап түмәрләр куелган. Түмәрләр ишеккә таба түбәнәя киләләр.* М.Хәбибуллин

**Түбәнәя тору** Әледән-әле яки даими рәвештә түбәнәю; билгеле моментка кадәр түбәнәю. --- *аның күңел кошы ашкынулы хисләр белән атна буе күкнең иң биек ноктасында кагынудан башлап, әкертен-әкертен түбәнәя --- торды.* Ә.Баян

**Түбәнәя төшү** Бераз түбәнәю; тагын да түбәнәю. *Татарлар хәзер Төркестанда сан ягыннан элеккедән дистәләрчә мәртәбә күбрәк, ләкин иҗтимагый тормышта әһәмиятләре бүген элеккедән бик нык кими, түбәнәя төшкән.* Т.Әйди

**ТҮБӘНГЕ** *с.* 1) Чагыштырмача уйсулык җирдә, түбәндә, аста урнашкан; аскы, астагы. *Уйларыннан арынып бетмәгән килеш кайтып җитеп капканы ачуга, тышкы баскычның түбәнге басмасында тезләрен кочаклап утыручы хатынны күреп, тәмам аптырашта калды.* Ә.Моталлапов. *Аннан соң инде сумкаңны тотып, тәмәке төпчекләре ташланган баскычлар буйлап түбәнге катка төшеп китәсең.* М.Галиев

2) Елганың тамагына якын булган. *Түбәнге Мисырда су июнь аенда күтәрелә башлый һәм сентябрь ахырына кадәр дәвам итә.* Н.Фәттах. *Соңгы вакытта, Иделнең түбәнге агымына йөри башлаганнан бирле, --- без Казанда элеккеге кебек еш булмыйбыз.* С.Сабиров

3) Иерархияле иҗтимагый системада башлангыч, беренчел. *Борынгы җәмгыятьнең иң түбәнге баскычын азык җыю хуҗалыгы, таштан ясалган эш кораллары, тотемизм һәм ыруглык строе гәүдәләндерә.* Ватаныбыз тарихы. --- *ул комсомолның түбәнге оешмаларына практик җитәкчелек итте, директивалар бирде, күрсәтмәләр басты, юллар күрсәтте, эш формалары турында фикер алышулар ачты, тәҗрибәләрен бүлеште.* Мирас

4) *иск.* Алдагы, киләсе, әйтеләчәк, күрсәтеләчәк. *Түбәнге мәкалә әнә шул көрәшләр вакытында пантюркизмга каршы фронт ягыннан әйтелгән фикер булды.* Г.Ибраһимов. *Без татар сүзләренең бу хасияте белән азрак файдалану өчен --- түбәнге ике кагыйдәне генә хәтердә тотарга кушабыз.* Г.Алпаров

5) *к.* **түбән 1.** (*12 мәгъ.*). *Италиядә парламентның түбәнге палатасын 630 депутаттан 512 гә калдырганнар.* Шәһри Казан. *Әлеге чарада Россия парламентының түбәнге палатасы башлыгы Борис Грызлов катнашкан.* Ватаным Татарстан

**ТҮБӘНДӘГЕ** *с.* 1) Астагы, аста урнашкан. *Түбәндәге атлылар, төяләләр ак чаршау өстендә кырмыскалар үрмәләгән төсле --- күренәләр.* Ш.Камал. *Түбәндәге рус авылында тынлык, юл буендагы телеграф баганалары карасу боз белән капланганнар.* М.Мәһдиев. *Ә беләсеңме, иң кызыгы шунда: мин һәрвакытта да түбәндәге җирне, урманнарны, елгаларны гел менә шулай, самолёт тәрәзәсеннән күргән кебек күрә идем.* Аманулла

2) Алга таба языла, күрсәтелә, сөйләнелә торган. *Кәгазьдә түбәндәге хәрефләр тезелгән иде ---.* Г.Афзал. *Кырымга патша исеменнән түбәндәге эчтәлекле хат җибәрелде ---.* М.Әмирханов

**ТҮБӘНДӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* Алга таба әйтелгәнчә, күрсәтелгәнчә, тасвирланганча. *Мәдрәсәдәге тормышның рәвеше түбәндәгечә иде: таң алдыннан, иртә намазыннан элек, шәкертләрнең һичберсе калмыйча урыннарыннан торырга мәҗбүрләр.* М.Гафури. *Мәгариф эшенә алга таба да даими игътибар бирүен ул бу эшкә зур милли вазифа йөкләнү белән бәйли һәм ул вазифаны түбәндәгечә аңлата ---.* Ф.Мусин

**ТҮБӘНЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **түбәнәю**. *Ай түбәнләнә һәм кызара, йолдызлар гүя күз яше аркылы карап елмаялар ---.* Ш.Камал

2) Түбәнчелек күрсәтү, тулысынча буйсыну; үз дәрәҗәсен төшерү. *Һич элекке төсле алдыңда түбәнләнмим хәзер; Без ераклаштык, ишет: син – син хәзер, мин – мин хәзер. Инде әмриткән сүзең дә аяте Коръән түгел* **---**. Г.Тукай. *Башта ул кыз белән карчык турында уйлады. Ни өчен алар бу чаклы түбәнләнәләр? Кемгә кирәк аларның ялагайлануы?* Г.Кутуй

3) *куч.* Үзен түбән җанлы кеше итеп күрсәтү, әшәкелек эшләү, кабахәтләнү, намуссызлану

4) *күч.* Үзен мәсхәрәле, намусына тия торган хәлдә тою; кимсенү, хурлану

**Түбәнләнә бару** Торган саен түбәнләнү

**Түбәнләнә башлау** Түбәнләнүгә таба бару

**Түбәнләнә төшү** Бераз түбәнләнү

**Түбәнләнеп килү** Әкренләп түбәнләнү

**Түбәнләнеп китү** Бер моменттан, бер җирдән башлап кинәт түбәнләнү. *Шуларны уйлагач, күзем түбәнләнеп, күңелем сүрәнләнеп китә, ә казакъ кардәшләргә карата ак көнчелек уяна.* Р.Гыйлемханов

**ТҮБӘНЛӘТҮ** *ф. к.* **түбәнәйтү**. *Син кешелекне түбәнләттең, җитәр, Мин сине сөймим шуңа, чиркин шәһәр.* С.Сүнчәләй. *Түбәнләттең үзеңне алдашып, юри гашыйк булып.* М.Җәлил

**ТҮБӘНЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **түбәнәю**. *Әйдәгез! Кояш бик түбәнләде.* М.Фәйзи. *Ул шәһәрләрне, авылларны яндырып, талап, Идел буйлап Хәзәргә кадәр түбәнләде.* И.Хуҗин

**Түбәнләп ташлау** Ачу, кызулык, ялгышлык белән түбәнләү. *Аермый башлады Яманны яхшыдан. Түбәнләп ташлыйлар Яхшыны шакшыдан.* И.Киньябулатов

**Түбәнләп тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта түбәнләү

**Түбәнли бару** Торган саен күбрәк түбәнләү

**Түбәнли башлау** Түбәнләргә керешү

**Түбәнли китү** *к.* **түбәнли башлау**. *Юлда Каран күперен чыккач та, минем бу юлдаш абзыкай җирән юргасын унга борды да, куаклык буйлата юырттырып, Кызыл Яр ягына түбәнли китте ---.* Казан утлары

**Түбәнли төшү** Бераз түбәнләү; тагын да түбәнләү. *Машинабыз бер үр менеп, бер түбәнли төшеп бара бирде.* Казан утлары

**ТҮБӘНЛЕК** *и.* 1) *геогр.* Океан өсте тигезлегеннән 200 метрдан биегрәк булмаган җирләр (гадәттә тигезлек). --- *Каспий диңгезе буендагы Каспий буе түбәнлегенең күбрәк өлеше океан өсте тигезлегеннән түбәнрәк ята (яр буенда 26–28 м га), амазонка түбәнлеге – океан өсте тигезлегеннән 200 м дан да югары түгел.* Физик география. *Көнбатыш Себер түбәнлегенә өлкәнең көнчыгыш өлешен биләп тора.* Фән һәм тел

2) Иңкүлек, иңкү җир; уйсулык. *Олы юлга чыга торган туп-туры озын урам, түбәнлектә урнашкангамы, карга чумып утыра.* А.Вергазов. *Авыл тау өстендә утырса да, аның болыннары, Сабантуй урыннары, көтүлекләре, хәтта күпмедер чәчүлек җирләре дә Агыйдел буендагы түбәнлекләрдә.* Ә.Моталлапов

3) *сөйл.* Тәбәнәк урын. *Бу су, ярларының түбәнлеге аркасында, әледән-әлегә суын эчендә сыйдыра алмыйча таша.* К.Тинчурин

4) *күч.* Намуссызлык, кабахәтлек; түбән теләкләр, түбән хисләр белән эшләнгән эш-гамәл. *Кыз бала ышаныч күрсәтә дип, андый түбәнлеккә бармыйлар инде.* М.Хәсәнов. *Кеше ни өчен газап күрә, төрле түбәнлекләр һәм рәнҗетүләргә дучар ителә?* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Мескенлек, фәкыйрьлек; кимсетелү; намуска тия торган хәл. *Ул минем белән авылдан авылга хәер сорашып йөрүне дә, дөньяда иң зур авырлыкны, түбәнлекне дә бергә кичерде.* А.Әхмәт. *Рядовой колхозчы булып калу башта аңа түбәнлек булып тоелса да, торабара анысына да күнегер, ул да бүтәннәрдән ким эшләмәс иде.* В.Нуруллин

6) *күч.* Сыйфаты яки санлы бәяләмәсе ягыннан түбән булу. *Кайбер язучыларыбыз үзләрендәге идея түбәнлеген яки идеясезлекне «матур форма», «матур сүзләр» белән капларга тырышалар.* Һ.Такташ. *Кыскасы, үзеңнең аз тәэмин ителгәнеңне, өйдәге температураның түбәнлеген исбатлау, лифтта йөрмәвеңне, лифтның эшләмәгәнлеген раслап йөрү – үзеңнең дөя түгеллегеңне дәлилләп йөрү белән бер булачак.* Татарстан яшьләре

7) *күч.* Кече күңеллелек, илтифатлылык, түбәнчелек. *Күтәрмә баш югары, кыл түбәнлек, Түбәнлектән табарсың күп иминлек.* Г.Утыз Имәни. *[Улың] түбәнлек белән гафу үтенсә, патшаның күңеле киң, бәлки, гафу итәр.* Г.Ибраһимов

**ТҮБӘ́Н ӨЙ** *и.* 1) Өйнең аскы каты (элекке бай өйләрендә ялчылар, асраулар һ.б. торган кат). *Түбән өйдә Сәлимә ыңгыраша.* Т.Гыйззәт. *Кодалар югары өйгә, кодагый белән кодачалар түбән өйгә керделәр.* Г.Бәширов

2) Идән асты. --- *әнисе үзе аңа [кызына] ярдәмгә килде: – Түбән өйгә төшер, кызым, – диде ул, чаршау артыннан чыгып. Сабира тиз генә идән капкачын ачты һәм әнисен өй астына төшерде...* Ф.Бәйрәмова

**ТҮБӘНСЕЛ** *с. диал.* Сөзәк, аска таба, түбәнгә табан авышлыгы булган. *Юл түбәнсел, әй, малай, сызам гына! Ургылып артта кала тузан гына.* Н.Исәнбәт

**ТҮБӘНСЕНҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәнең биеклеген җитәрлек дип тапмау, түбән дип санау

2) Кимсенү, гарьләнү, хурлану, кимлек санау. *Хәдичәнең түбәнсенүен күрү Вәлинең күңеленә хуш килде булса кирәк.* М.Хәсәнов. *Ниндидер моңарчы сизелмәгән сагыш, кимсенү, түбәнсенү, юксыну бар иде анда.* А.Гыйләҗев

3) Баш ию, үз дәрәҗәсен төшерү, мескенләнү. *Барма, Халикъ. Барма, зинһар, шул әшәке йортка, түбәнсенмә. Ансыз да яшәрбез әле.* С.Сүнчәләй. *Мирсәет абыйларга керергә уңайсыз, ул олы кешене тынычсызлау булыр, бәлки, Сөләй белән Кәрим алдында түбәнсенергәдер?* Г.Тавлин

**Түбәнсенә төшү** Бераз түбәнсенү

**Түбәнсенеп йөрү** Озак вакыт, гел түбәнсенү. *Көтелмәгән бәлаләрдән, ятлар каршына барып, түбәнсенеп йөрүләрдән үзең сакла!* В.Имамов. *Ә Илнар китте. Мәхәббәт сорап, түбәнсенеп йөрмәде, китте дә барды.* Г.Гыйльманов

**Түбәнсенеп тору** Хәзерге моментта түбәнсенү; гел, әледән-әле түбәнсенү

**ТҮБӘНСЕНҮЛЕ** *с.* 1) Кимсенүле, гарьле, хурлыклы. *Аны да түбәнсенүле һәм әрнүле картлык көтәрме?* Д.Булатова

2) Кимсенү, гарьлек, хурлык хисләрен белдергән, шуларны чагылдырган. *– Миңа нинди эшегез төште соң? – диде Җирән, ниһаять, мескен, түбәнсенүле тавыш белән.* Казан утлары

**ТҮБӘНСЕТҮ** *ф.* 1) Кимсетү, кемнең дә булса горурлыгына кагылырлык берәр нәрсә әйтү яки эшләү; кешенең дәрәҗәсен төшерү. *Ни өчен түбән-*

*сетергә, мыскылларга, мәсхәрәләргә тырышты мине Оля?* Г.Тавлин. *Максим Горькийдан башландымы икән ул? Аның Сатин дигән герое, шулер, айнымас бәндә: «Җәлләп кешене түбәнсетмә!» – дип акыл сата ич. Түбәнсетмә, имеш!..* Б.Камалов

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса әһәмиятен, ролен киметеп, кечерәйтеп күрсәтү. *Ашыгу кешене кечерәйтә, түбәнсетә.* А.Гыйләҗев. *Сезнең хезмәтегезне аз гына да кечерәйтергә, түбәнсетергә теләмим.* Р.Мирхәйдәров

**ТҮБӘНСЕТҮЛЕ** *с.* Кимсетүле, гарьләндергеч, хур итә торган, мәсхәрәле. *Сүз арасында кыстырган репликалары кинаяле, катгый, түбәнсетүле төсмерләргә бай.* М.Галиев. *Сөйләшү ике як өчен дә авыр, төртмәле, түбәнсетүле дулкында чайкалды.* Т.Галиуллин

**ТҮБӘНСУ** *с. ким. дәр. к.* **түбән 1.** (*1 мәгъ.*). *Түбәнсу урыннарда бик куе булып кыяклы үлән үсә, моны терлек ашамый.* Г.Бәширов

**ТҮБӘНТЕН** *рәв.* 1) Җир өстенә якын; астан гына, биектән түгел. *Аннары, әйдә, алайса куып тотып кара дип, хәшәрәт кош, түбәнтен генә очып, тауга таба китте.* В.Нуруллин. *Кояшсыз, авыр көн: карасу болытлар түбәнтен генә агыла, агач ботаклары җилдә чайкала.* Р.Кәрами

2) *диал.* Берәр нәрсәнең түбәнге ягыннан; төптән, астан өскә таба. *Бу вакытта ерактарак түбәнтен менеп килгән зур гына пароход күренде.* Р.Гали

**ТҮБӘН ТӨЗЕЛЕШЛЕ** *с. биол.* Үсешнең иң түбәнге, беренчел этабында торган. *Туфрак барлыкка килүдә түбән төзелешле үсемлекләр ---, югары төзелешле үсемлекләр һәм хайваннар катнаша.* Дарвинизм нигезләре. *Палеозой эрасы башында түбән төзелешле умырткалылар (балыклар) килеп чыга.* Биология

**ТҮБӘНЧЕЛ** *с. сир.* 1) Шактый түбән, биек булмаган

2) Түбәнчелекле, кече күңелле; эреләнү, һавалану гадәте булмаган. *Зыя Камали җәнаблары исә – бөтенләй башка зат. Аның кечелекле, садә, түбәнчел булуы хәйран калдыра.* С.Поварисов

3) Түбән, гади, тупас; әшәке, бозык. *Белеп әйтәләр шул: кара сөяк түрә булса, сәясәте тамак туйдыру, киенү ише түбәнчел ихтыяҗларны гына үтәүгә кайтып кала, милләтне кайгырту аның башына да килми.* Т.Әйди

**ТҮБӘНЧЕЛЕК** *и.* 1) Кече күңеллелек, илтифатлылык. *Вахитов исемендәге колхозның алдынгы терлекчесе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Миңзифа Галимуллина, герой якташына түбәнчелек белән баш иеп, чигүле сөлгедә ипи-тоз тәкъдим итте.* Г.Тавлин. *Алар аңа бик түбәнчелек белән, бик кызганып карап, барысын да тәфсилләп аңлаттылар, тагын кайсы больницага барып карарга мөмкин икәнен әйттеләр.* М.Вәлиев

2) Ихтирам, күндәмлек, буйсынучанлык. *Әй безнең бөек, тирә-якта данлыклы патшабыз, --- барлык патшалар сиңа бик түбәнчелек белән карыйлар, синнән куркалар.* Әкият. *Баш министр Витте исеменә мөселманнарның ихтыяҗын түбәнчелек белән белдергән петицияләр җибәрү эше башлана.* И.Нуруллин

3) Дәрәҗәне төшерә торган нәрсә, хурлык, гарьлек. *Горький, Ленин белән шахмат уйнаган Горький, гади кешеләргә дә ихтирам күрсәтә, алар белән уйнауны да түбәнчелек дип санамый икән!* Җ.Фәйзи. *Сер бирмәсә дә, Вәсим хатынын көн дә көтте. Барып алмаса, кайтмасын да чамалады, хатын артыннан ялынып баруны түбәнчелеккә санады.* Ә.Моталлапов

4) *күч.* Түбәнлек, намуссызлык, кабахәтлек. *Белмәдек – без кичермәгән түбәнчелек калмады ---.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ТҮБӘНЧЕЛЕКЛЕ** *с.* Кече күңелле, үзеннән кечерәкләргә, түбән дәрәҗәдәгеләргә илтифатлы, игътибарлы; характерына эреләнү, һавалану хас булмаган. *Аларның түбәнчелекле булуы, нәзакәтлелеге, үз өстенлекләрен яшереп, икейөзлеләнүләре... О, ачыктан-ачык мыскыллап карау никадәр татлырак, ә мондый хәер бирүләр ничек түзгесез!* В.Леви

**ТҮБӘСЕННӘН** *рәв.* Түбәләмә, туп-тулы итеп, сыйдыра алган хәтле; мөлдерәмә итеп. *Беренче колымашканы түбәсеннән өеп төядек.* Л.Гыйззәтуллина. *--- әбекәйнең яңа ипие мичтән чыгарылган, мендәр өстенә икенче ягы белән әйләндереп тезелгән, күпереп пешкән көлчәсе майлап, табак түбәсеннән итеп өеп куелган, мунчасы ягылган була иде.* Э.Шәрифуллина

**ТҮБӘ́СЫМАН** *с.* **1.** Формасы, ясалу рәвеше белән түбәгә охшаган

**2.** *рәв. мәгъ.* Түбәгә охшатып. *Буртның өстен түбәсыман итеп очлыйлар һәм калын катлау салам белән каплыйлар.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

**ТҮБӘ ТАКТА** *и. диал. к.* **түшәм**

**ТҮБӘТӘЙ** *и.* 1) Гадәттә бизәкләп эшләнгән, җиңел, сай түгәрәк ир-ат баш киеме. *[Айрат] Буләккә әтисе яратып кия торган тирән түбәтәй дә алган.* Б.Камалов. *Бакый ага киез итектән, башында киез түбәтәй, алдына озын эш алъяпкычы япкан...* Л.Шагыйрьҗан

2) *анат.* Күшәүче хайваннарның ашказанының икенче бүлеме; *русчасы:* **сетка**. *Беренче бүлектә – картада үсемлек азык микроорганизмнар ярдәмендә әчи һәм түбәтәй картага этеп кертелә.* Биология

3) Самавыр кайнап чыкканнан соң, төтен чыкмасын өчен, күмерлегенең өстен томалап куя торган капкач; кәлпәк

◊ **Түбәтәй белән киңәшү** Үз алдына уйлану, үзенчә фикер йөртү. *Мәнә мин, баш вата торгач, каеш түбәтәем белән киңәшә торгач, яшьләр арасында Вәрәшбашта синнән дә намуслырак кеше юк, дигән фикергә килдем бит, әй...* Г.Ахунов. *Түбәтәең белән киңәш башта: Хәрәкәт ит уйлап һәр сүзең; Бүрек белән бәреп егып булмый: Киртәләр бар алда. Бул түзем.* Ә.Рәшит. **Түбәтәй җыеп калу** Берәр эшнең, вакыйганың иң мөһим өлешендә катнаша алмый калу, җитешмәү, кешедән артта калу

**ТҮБӘТӘ́Й АЛУ УЕНЫ** *и.* Каравылчылы уеннарның бер төре

**ТҮБӘТӘЙЛЕ** *с.* Түбәтәе булган, түбәтәй кигән. *Ильяс бабай, яланаяк хәлдә, түбәтәйле башына яшькелт эшләпәсен кигән килеш --- үз бәхетенең никадәр зур икәнлеген карарга, күзәтергә кереште.* Ә.Баян

**ТҮБӘТӘЙЧӘН** *рәв.* Бары түбәтәй кигән килеш, аның өстеннән җылырак баш киеме кимичә яки чалма чалмыйча. *Нәгыйм абзый шинель киеп, каеш буып алган да, фуражкасын салып, түбәтәйчән генә утыра.* Ә.Фәйзи

**ТҮБӘ-ТҮШӘМ** *и. к.* **түшәм**. *Йортның түбә-түшәмен яңартканнар, тышкы яктан шәп такталар белән тышлаганнар.* В.Имамов. *Сәнҗәрә, тәрәзәдә шәфәкъ яктысы сүнеп, бүлмә эче караңгылык белән тулганчы, түбә-түшәмгә текәлеп өнсез ятты.* Л.Зөлкарнәй

**ТҮБЕР** *и. диал.* 1) Түп. *Җитен түбере. Чәй түбере*

2) Кайбер орлыкларны балда катырып ясалган татлы ашамлык; козинаки. *Хәсән Сарьян белән базарга көнбагыш түбере эзләп бардык.* Т.Миңнуллин

**ТҮБЕШ** *с. диал.* Тәбәнәк, карсак. *Бу хатын белән янәшә түбеш буйлы, юан, чыршайган битле карт бер карчык [басты].* Атака

**ТҮГӘ** *ы. к.* **түгәнәй**. *Аның өчен ак халатлы апаларның, чүгәләп утырып, без-без сөт савулары да, түгә, түгә дип эндәшүләре дә [кызык].* Г.Гобәй

**ТҮГӘНӘ** *и. сөйл.* Сыерны яратып атау, чакыру сүзе

**ТҮГӘНӘЙ** *ы.* **1.** *к.* **түгәнә**. *Сыер сауган җиреннән: «Түгәнәй, ал әле аягыңны», – дип сыерга дәшсә дә, өйгә кергәч, аңардан Зәбире сорау ала: «Абзарда кем белән сөйләштең?»* Н.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Сыер. *[Ул], түгәнәйне әйбәтләп савып, өенә кайтып китте.* А.Расих

**ТҮГӘНИ** *ы. к.* **түгәнә**

**ТҮГӘРӘ́ГАВЫЗЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Теш казналары булмаган, балыксыман умырткалы хайваннар классы (мәс., миногалар)

**ТҮГӘРӘК** *с.* **1.** 1) Шар, боҗра, әйләнә формасындагы. *Кайда гына яшәсәм дә түгәрәк Җир шарында, Күңелкәемкүбәләгем Туган-үскән ягымда.* Х.Туфан. *Бүлмәм эче гади генә бизәлгән: түгәрәк өстәл, карават, шифоньер, тумбочка, урындыклар.* Л.Шагыйрьҗан

2) Почмаклары, чыгынтылары булмаган, кырлары йомры, түгәрәкләнеп торган. *Кыз, туган авылын карбызга охшатып кәгазьгә төшерде дә, читчитләренә хач галәмәтләре куя-куя, борчак шикелле түгәрәк саннар тезде.* Ш.Рәкыйпов

3) *мат.* Вак берәмлекләрсез, вакланмалар белән белдерелмәгән, бөтен саннардан гына торган (саннар тур.)

4) *физ.* Урта бер ноктада барлыкка килеп читкә табан тарала торган (дулкыннар тур.)

5) *хәрби* Камалышта калган очракта теләсә кайсы яктан килгән дошманга каршылык күрсәтерлек итеп, йомык әйләнә ясап корылган. *Без, уңай үргә күтәрелеп, түгәрәк оборона кордык.* Г.Әпсәләмов

6) *күч.* Кыска һәм тыгыз, тулы, симез, юан, йомры (гәүдә төзелеше тур.). *Түгәрәк битле, чал сакаллы карт, башында кара бәрхет түбәтәй, таш балбалнысыдай нык, чыдам гәүдә.* В.Юныс. *Бу, йомгак кебек түгәрәк, кыска буйлы, кыска аяклы капитанның яңадан нәрсәдер төпченә башлавы аңа әле аңлашылып җитми иде.* З.Фәтхетдинов

7) *күч.* Һәр яктан канәгать булырлык, бөтен җире килгән, тулы, җитеш. *Табак-савыт ватылмады: яшәп киттеләр, тормышлары түгәрәк.* Ш.Рәкыйпов. *Утырыйкчы бергәләп; Моңаеп та көлгәләп. Ай да чыкты тәгәрәп, Безнең дөнья түгәрәк!* Ш.Галиев

8) *күч.* Уртача, якынча, гомумиләштереп алынган, түгәрәкләнгән. *Статистика өчен түгәрәк сан бирү*

9) *күч.* Кешенең тууына, нәрсәнеңдер нигез салынуына, ачылуына һ.б.ш.ларга билгеле ел тулган, гадәттә тантаналы төстә билгеләнә торган юбилей туры килгән (дата, ел, көн). *Кырык яшь – зур бәйрәм, түгәрәк дата.* Г.Ахунов. *Бәйрәмнәрдә түгәрәк даталар тәэсирлерәк. Әйтерсең лә аермасы бар! Аермасы көнендә түгел, вакыйгасында.* Ш.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Әйләнә, боҗра. *Бу электроннар бәйләме үзенә махсус экран өстенә барып төшеп, аның шул урынында кечкенә генә түгәрәк рәвешендә яктырыш тудыра.* Физика курсы. *Лишайникларның төрле төрләре күп урыннарда: Африка чүлләрендә дә, Поляр түгәрәк артында да һәм Төньяк боз океаны ярлары буенда да таралган.* Робинзон эзләреннән

2) Әйләнә, боҗра формасында булган яки махсус шул формада ясалган әйбер, әсбап. *Әнә шул мунчадан чабынып чыкканда, сине --- аш тәлинкәсенә өелеп, һәр түгәрәгә дүрткә киселеп, өстенә өчаякта эретелгән кайнар май коелган бер түбәләмә бәрәңге пәрәмәче көтә инде!* М.Мәһдиев. *Бөке изоляциягә, коткару түгәрәкләре, шлемнар, олтаннар ясауга китә.* Робинзон эзләреннән

3) *геом.* Яссылыкның әйләнә белән чикләнгән өлеше. *Бу күренеш – гөмбәләрнең түгәрәк ясап үсүе – болай аңлатыла. Гөмбәлек туфракта түгәрәк ясап үсә, ә уртасыннан үлә бара.* Робинзон эзләреннән

4) Тыгыз булып баскан яки утырган кешеләр хасил иткән әйләнә, боҗра. *Көрәшчеләр таза, арка-җилкә калын, корсак та саллы. Менә түгәрәк уртасында берсен берсе этеп сөзешеп йөриләр ---.* М.Мәһдиев

5) Түгәрәкле уйнау, гомумән күмәк җырлы-биюле уеннар, кичәләр барган урын, мәйданчык. *Кызлардагы уңганлыкны Уенда да күреп була: Түгәрәкнең уртасында Гөлләр үскән кебек була...* Х.Әюп. *Рәхмәтулланың кулын кыстылар, мактадылар, түгәрәк уртасына Рәхимә белән икесен чыгарып җырлаттылар.* Б.Камалов

6) *күч.* Уртак кызыксыну, шөгыль, хобби нигезендә берләшкән кешеләрдән торган, гадәттә иҗади юнәлештәге иҗтимагый оешма. *Драма түгәрәкләре гөр килә, яшьләр ялындырып тормый, театр уйныйлар, концертларда катнашалар.* Г.Ахунов. *Сугыштан соң илебезнең күп кенә шәһәрләрендә аквариумчылар түгәрәкләре һәм клублары эшли башлый, регуляр рәвештә күргәзмәләр оештырыла, китаплар чыгарыла.* Кызыклы ихтиология

7) *күч.* Бер төрле мәнфәгатьләр, аралашу һ.б.ш. берләштергән кешеләр төркеме; даирә. *Аның катнашкан һәм дус булып йөргән кешеләре билгеле бер кечерәк түгәрәктән гыйбарәт булган.* Г.Рәхим

**ТҮГӘРӘКЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Түгәрәк хәлгә китерү. *Кул чабуларны бетерергә теләгәндәй, [С.Сәйдәшев] халыкка*

*арты белән борылды, ике кулын да туп тоткандай түгәрәкләндереп күтәрде.* Җ.Фәйзи. --- *старшина сафның уң як башында, күкрәген тәгәрмәч кебек түгәрәкләндереп торган, буеның озынлыгы ике метрга якын булган таза солдатка атның тезгенен сузды.* З.Зәйнуллин

2) Түгәрәкләү, чама белән, якынча итеп алу, гомумиләштерү

**Түгәрәкләндереп кую** Түгәрәк хәлгә китерү

**Түгәрәкләндереп тору** Түгәрәк хәлдә тоту

**ТҮГӘРӘКЛӘНЕШ** *и.* Түгәрәкләнү процессы

**ТҮГӘРӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Түгәрәк (*1 мәгъ.*) хәлгә килү, түгәрәк формасын алу. *Чәчәкле маркизет күлмәге, аяк астыннан ук түгәрәкләнеп, муенын каплаган.* М.Мәһдиев. *[Абага яфракларының] Икенче рәт өлешләре сузынкы, тешле-тешле, очлары түгәрәкләнгән.* Урман аптекасы

2) Түгәрәк (*4 мәгъ.*) хасил итү, түгәрәк төзү. *Ә кызлар түгәрәкләнеп басканнар да салмак кына чайкалып бииләр.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Тулылану, тәнгә утыру, тазару; юанаю, симерү. *Тазарып, түгәрәкләнеп, алсу йөзле чибәр егеткә әйләнеп китте Лотфулла.* З.Зәйнуллин. *Инде Искәндәр – өлгереп җиткән ир-егет, Үлинәнең дә гәүдәләре тагын да зифаланып, күркәмләнеп китте, күкрәкләре калку, балтырлары түгәрәкләнде.* Р.Фәизов

4) *күч.* Бетү, тәмамлану, ахырына җитү, төгәлләнү; йомгаклану, ябылу. *Каршы тавыш биреп маташмасам, йөз процент белән түгәрәкләнә иде бит нәтиҗә.* Ф.Баттал. *Хәзер ул тулып түгәрәкләнгән, яшьлек сәламәтлеге бөркеп торган ап-ак йөзенең бит алмаларына алсу төс йөгергән.* Л.-Х.Таналин

5) *күч.* Һәр яктан да җитеш хәлгә килү, канәгатьләнерлек дәрәҗәгә җитү. *Квартир хакы арзан: өч бүлмәсенә 17–18 сум түлиләр. --- Тормыш бар җәһәттән дә түгәрәкләнә.* А.Гыйләҗев. *Килене белән улы да кайткач, табын тәмам түгәрәкләнә.* Җ.Рәхимов

6) *күч.* Камилләшү. *Телнең үзәкасылын тәшкил иткән төп сүзләр, гасырлар буена чарланып, түгәрәкләнеп, камил рәвешкә кергәннәр.* М.Галиев

**Түгәрәкләнә төшү** Бераз түгәрәкләнү; тагын да күбрәк түгәрәкләнү. *Юк, гап-гади бөтен икмәк кенә түгел, ул... кадерлем, ул түгәрәк ипи – туендыручыбыз җир-ана үзе, тагын да түгәрәкләнә төшкән бәхет, тормышның дәвам итүе...* Ш.Рәкыйпов. *Вакыт үзенекен иткән, икесе дә түгәрәкләнә төшкән [егетләр].* Р.Мөхәммәдиев

**Түгәрәкләнеп җитү** Тәмам, тулысынча түгәрәкләнү. *Сакалы да түгәрәкләнеп җитмәгән рәссам егет түр стенага --- өр-яңа өндәмә кертеп элде.* Ф.Баттал

**Түгәрәкләнеп калу** Берәр тәэсирдән түгәрәк хәлгә килү. *Председательнең күзләре яңа уенчык күргән сабый баланыкыдай түгәрәкләнеп калды.* Җ.Дәрзаман

**Түгәрәкләнеп килү** Түгәрәкләнүгә таба бару, түгәрәкләнә башлау; аз-азлап тигез түгәрәк торыш алу. *Нәкъ үзе – түбә. Гөмбәз. Күрмисеңмени: түгәрәкләнеп килгән.* Ә.Гаффар. *Түгәрәкләнеп килгән җыйнак гәүдә, үзенә килешеп торган туры аяклар, төз һәм озын муен, текә маңгай – һәммәсе зифалык һәм гайрәт турында сөйли.* Р.Мөхәммәдиев

**Түгәрәкләнеп киту** Соңгы арада сизелерлек түгәрәкләнү. *Эдик түгәрәкләнеп киткән иде. Өстендәге кара шевиоттан теккән униформадан корсагы беленә.* М.Юныс. *Таныш «исәнмесез»ләрне ишеткәч, бөтенләй дә дөньялар түгәрәкләнеп китте.* Э.Гарипова

**Түгәрәкләнеп тору** Түгәрәк формада булу, түгәрәк булып күренү. *Ул олыгайган, ләкин түгәрәкләнеп торган иреннәре һәм уйчан кара күзләре һаман шул килеш.* Җ.Фәйзи. *Әйтерсең лә офыккача түгәрәкләнеп торган бу җирнең йөрәге шулай тибә иде.* Ә.Гаффар

**ТҮГӘРӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Түгәрәк формасы бирү, түгәрәк итеп ясау, түгәрәк барлыкка китерү. *Стаканның капкачында түгәрәкләп уелган аралык бар, аның аша даими магнитик агыш үтеп тора.* Физика курсы. *Папирусның кипкән озын тасмаларын түгәрәкләп төргәннәр.* Робинзон эзләреннән

2) Исәпләгәндә вакланмаларны яки чагыштырмача вак саннарны исәпкә алмау, эре берәмлекләрне генә күрсәтү; түгәрәк санга китерү. *Ярар, бер-ике тапкыр Мәдинә карышмады, саннарны аз-маз гына «түгәрәкләүгә» риза булды.* М.Хәсәнов. *Ләкин нинди дә булса металлның, мәсәлән, шул ук цинкның якынча, түгәрәкләп алынган атом авырлыгын үлчәүдән дә җиңел нәрсә юк.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

3) *күч.* Тәмамлау, бетерү, очына чыгу; ахырына кадәр җиткерү, йомгаклау, төгәлләү. *Эшләремне түгәрәкләп, троллейбус тукталышына килдем.* Б.Камалов. *Шуңа күрә сөйләшүне тиз тотарга, кабул итәрдәй карарларны кабул итеп, эшне ике-өч сәгатьтә түгәрәкләргә кирәк.* З.Фәйзи

4) *күч.* Билгеле яшькә җитү, шул яшьне тутыру. *Элек Галимҗан Ибраһимовларның күршесендә генә яшәгән Фәсәхәт абыстай (ул инде йөз яшьне түгәрәкләде) күпне сөйли.* С.Поварисов

5) *күч.* Йомгаклау, нәтиҗә ясау, гомумиләштерү. *Түгәрәкләп әйткәндә, кыйммәт бәягә нефть сатудан кергән барлык өстәмә табыш менә шул рәвешле әрәм-шәрәм ителә.* Ватаным Татарстан

6) *күч.* Камилләштерү, тулыландыру, шомарту, стилистик яктан эшкәртү. *[Хәйдәр] иң гади нәрсәләрне дә йотлыгып тыңларлык итеп түгәрәкләп, җанландырып сөйли белә.* Г.Бәширов

**Түгәрәкләп бетерү** Тәмам түгәрәкләү

**Түгәрәкләп җибәрү** Бераз түгәрәкләү

**Түгәрәкләп кую** Түгәрәк хәлгә китерү; тәмамлау, соңгы ноктаны кую. *Шапырай карт кемнәндер папирос алып кабызды. Аннары: – Менә шул! – дип сүзен түгәрәкләп куйды.* М.Хәсәнов. *– Тормышым авыр, дип рухыңны төшермә, сеңлем! Бер михнәтнең бер рәхәте булмый калмас барыбер, – дип юатып, фикерен түгәрәкләп куйды ул.* З.Фәйзи

**Түгәрәкли төшү** Аз гына түгәрәкләү; тагын да ныграк түгәрәкләү

**ТҮГӘРӘКЛЕ** *и. этн.* Авыл яшьләренең кулга-кул тотышып, берәр көйгә җыр җырлап түгәрәк ясап әйләнеп йөрү, уртага чыгып җырлау, бию, такмак әйтү кебекләрдән гыйбарәт күмәк

уен. *Түгәрәкле уйнаганда, Әйләнеп җырлаганда, Түгелә йөрәк серләре Чишмәдәй кайнап анда.* Ш.Маннур

**ТҮГӘРӘКЛЕК** *и.* 1) Түгәрәк форма. *Кызның каршындагы киң җилкәле ир --- йонлач бүреген башыннан суырып алгач, озынча чәчләре күперде дә, зур карбыздай башы түгәрәклеген җуйды.* М.Хуҗин

2) *күч.* Күңел тынычлыгы, канәгатьлек. *Бергә чакта ни дип энәләнәбез соң без, ни дип бер-беребезнең түгәрәклеге турында кирәгенчә уйламыйбыз?..* Б.Камалов

**ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ** *и.* Катнашучылары бертигез хокукта, статуста булган, гадәттә бер генә мәсьәләне тикшерүгә багышланган очрашу, киңәшмә формасы. *Семинар дәресләр, гадәттә, сорау-җавап рәвешендә корыла, ләкин без түгәрәк өстәлләр, киңәшмәләр рәвешендә дә эшләрбез.* Х.Ширмән

**ТҮГӘРӘК УЕН** *и. этн. к.* **түгәрәкле**. *Кино беткәннән соң түгәрәк уен башланган иде. Зәмзәмбикә белән алар клубтан бергә кайтып киттеләр.* М.Мәһдиев. *--- без, өлкән егетләрнең бот араларына кысылып булса да, анда үтәргә тырышабыз, авыз суыбызны корытып, яшьләрнең бишле-сигезле, түгәрәк уен уйнаганнарын карап торабыз.* М.Маликова

**ТҮГӘРӘКЧӘ** *рәв. мат.* **1.** Түгәрәк рәвешендә; түгәрәк нигезендә. *Яссылыкны түгәрәкчә үлчәү*

**2.** *с. мәгъ.* Тригонометрик. *Түгәрәкчә функцияләр*

**ТҮГӘРӘКЧЕ** *и.* Түгәрәк **2.** (*7 мәгъ.*) әгъзасы, түгәрәк эшчәнлегендә катнашучы кеше

**ТҮГӘРӘКЧЕЛЕК** *и.* Берәр түгәрәкнең, оешманың тар максатлар, мәнфәгатьләр белән генә чикләнгән эшчәнлеге. *Түгәрәкчелек стадиясеннән чыгып, яңа гына оешма булып әверелгән социал-демократлар «Уралец» типографиясеннән нык кына файдаланганнар.* И.Нуруллин

**ТҮ́ГЕЛ** *кис.* **1.** 1) Барлык мөстәкыйль сүз төркемнәренә, исем фигыльгә, хәл фигыльгә, киләчәк заман хикәя фигыльгә һәм кайбер модаль сүзләргә өстәлеп, шулардан аңлашылган нәрсәләрнең юклыгын белдерә. *Шәһәрнеке булып беталмадың, Түгел инде авылныкы да син; Үзеннән һич өстен булмый кеше, Кая гына кереп укымасын!* Х.Әюп. *Белеп тор: мин явыз түгел, әмма усал – Бөтен гомерем булыр шуңа ачык мисал!* Л.Шагыйрьҗан

2) Юклык формасындагы хикәя фигыль яки *юк* сүзе янында килеп, шулардагы инкяр итүне раслауга әйләндерә. *Балалар теле ачылганда матур. Туган теле дә булса! Теле ябылган, телен тешләгән очраклар да юк түгел.* Ш.Галиев. *Кайттылар ич, хәбәрсез югалды, үлде дигән хәбәрләре килгәннәр дә кайтмады түгел.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *терк. мәгъ.* 1) Ике нәрсәне берберенә каршы куйганда кулланыла. *Ул [Ә.Афзалова] халык мәхәббәтен, митингтан митингка чабып, кызыл сүзләр кычкырып түгел, ә авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә ерак юллар гизеп, туган халкын моң белән сугарып яулап алды.* Л.Шагыйрьҗан. *Катылык ягыннан беренче урында хәзер табигый алмаз түгел, ә ясалма боразон тора.* Химиянең киләчәге

2) Ике нәрсәне бер-берсенә каршы куйганда, икенчесенең беренчесеннән өстен булуын белдерер өчен, «аның турысында әйтеп тә торасы юк» мәгънәсендә кулланыла. *Сөйләшеп күрешергә түгел, хат алышырга да синнән башка кешем юк.* К.Тимбикова. *Ә мин тәмәкенең төтенен түгел, исен дә сөймим.* А.Хәсәнов

**ТҮГЕЛЕП** *рәв.* 1) Җәелеп, иркенләп, рәхәтләнеп (сөйләшү тур.)

2) Бик нык, онытылып, бирелеп. *Көтелмәгән бу бәладән әни бахыр ауный-ауный түгелеп елады.* Ф.Мансуров. *--- мескен генә кыяфәттә утырып торган Галияне кочаклап та алды, түгелеп елый да башлады.* Д.Булатова

**ТҮГЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **түгү**. *Бик күп кыйммәтле нәрсәләр һавага оча, суга түгелә, чыгарып ташлана, яндырыла, төрле юллар белән юкка чыгарыла.* Химиянең киләчәге

2) Сыек нәрсәләр савыты тулып, чайпалып, ташып чыгу. *Түгелергә торган чиләккә бер тамчы су җитә, чиләк тулды, тулышты һәм ага башлады ---.* А.Гыйләҗев. *Түгелмәсен дигәндәй, сөт тулы чиләкләрен сак кына алъяпкычларына таба елыштырып куйдылар.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч. шигъ.* Тыелгысыз рәвештә, бик җиңел, үзлегеннән язылу, әйтелү. *Ни-нәрсә түгелер ак кәгазьгә каләм очыннан: сүз-акыл вә хис-тойгы җәүһәрләреме, коры шапырынулармы?* С.Поварисов. *Ләкин ул Заһир абыйның күзеннән сирпелгән ялкынны да, минем күңелемнән түгелгән ялваруны да тоймады.* М.Маликова

4) *күч.* Таралу (тавыш, моң, нур һ.б.ш. тур.). *Өздереп нигә карадың, Ник тоттың чиләгемнән? Суларым түгел, ялкыным Түгелде йөрәгемнән.* С.Хәким. *Аркасыннан чәченә кушып үргән Тәңкә чыңы җиргә түгелә.* Х.Әюп

5) *күч. иск.* Берәр юнәлештә күпләп бөтен массасы белән кинәттән ябырылып керү; агылу (кешеләр тур.)

6) *күч.* Тотылу, сарыф ителү. *Язмышым хәл ителгән иде инде. Нәтиҗәдә көч бушка түгелде, вакыт әрәмгә китте.* М.Юныс

**Түгелеп алу** Берара, бераз түгелү. *Матур көннәре һәм төннәре белән башланып киткән гаилә тормышларының бәхет тустаганы менә шулай чайкалып китте, түгелеп алды.* Ф.Яхин

**Түгелеп бетү** Ахырына кадәр түгелү, бөтенесе түгелү. *Соң, малакай, син дигәнчә булса, ул диңгез һәм елгаларның суы әллә кайчан түгелеп беткән булыр иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Нәфисә чиләген тагын аска төшерә, тагын шул ук хәл: чиләктәге суы чайпалып, түгелеп бетә...* Г.Гыйльманов

**Түгелеп калу** Түгелеп, шул хәлен саклау; бөтенләйгә түгелү. *Яшерен генә туган серләре Фазылның фотосы алдында түгелеп калды...* Ф.Яхин

**Түгелеп китү** Кисәк түгелү. *Тәрәдем башны тәрәзгә, Күңелем китте түгелеп. Безгә ят түгел болытлар, Болытлар безгә ят түгел.* Р.Зәйдулла. *Түгелеп китәргә торган чүлмәк кебек тулышып йөрдем.* Ф.Яхин

**Түгелеп тору** Даими түгелү; хәзер түгелү; түгелгән хәлдә булу. *Аның йөзенә әллә нинди кызару чыккан, күзләрендә шатлыкны яшерә алмаенча нур түгелеп тора, селкенүенә, йөрүенә, кы-*

*лынышына тизлек, егетлек кушылган.* Г.Исхакый. *Ил сагышы тулып, түгелеп тора Дөнья белән бәхилләшү сазымнан.* Ф.Гыйззәтуллина

**Түгелеп яту** Түгелгән хәлдә булу. *Шаулап килеп кергән чит кешедән өркегән Елгыр, түгелеп яткан солыдан аерылып, читкә тайпылды.* Г.Гыйльманов

**ТҮГЕЛҮ-ЧӘЧЕЛҮ** *ф.* 1) Агучан, сибелүчән нәрсәләр таралу, сибелү

2) *күч.* Әрәм-шәрәм булу, юкка югалу. *Андый чакларда әйтерсең лә аның аккордеонынннан көй түгел, ә бер күңелдән икенче күңелгә, беркая түгелмичәчелми, беркем колагына чалынмый, икәүгә генә аңлаешлы сер агыла...* М.Маликова

3) *күч.* Барлык серләрне ачу, фикер-карашлар белән уртаклашу

**Түгелеп-чәчелеп бетү** Нык түгелүчәчелү. *Юк, түгелеп-чәчелеп бетү бер дә әйбәт түгел.* В.Имамов

**ТҮГЕ́М КӨНЕ** *и. этн.* Керәшен татарларында үлгән кешеләрне искә алу көне. *Узган атнада кайбер керәшен авылларында Түгем бәйрәмен уздырдылар.* А.Сәлимов

**ТҮГЕ́М-ЧӘЧЕМ** *җый. и.* 1) Коелып, түгелеп, чәчелеп калган нәрсәләр, вак-төяк югалтулар

2) *иск.* Кеше үлгәч, садакага өләшелә торган нәрсәләр, акчалар. *Ул 11 октябрьдә – түгем-чәчем көнне – безнең Сарман ягындагы Нарат Астында элгәредән үк кызыл һәм шикәр чөгендереннән, кишердән пируклар пешерә халык.* Туган як

**ТҮГЕНДЕ́-ЧӘЧЕНДЕ** *җый. и. к.* **түгем-чәчем** (*1 мәгъ.*)

**ТҮГЕНТЕ** *и.* **1.** Төрле хуҗалык предприятиеләренең файдаланылган, төрле техник һәм биологик калдыклар белән пычратылган, түгелә торган сулары

**2.** *с. мәгъ.* Пычрак, түгелергә тиешле, түгелә торган

**ТҮГЕШ** *и.* Түгү күренеше, түгү эше. *Тук башаклар – Алла бирмеше һәм игенченең хезмәт җимеше: Таңнан төнгә тикле тир түгеше, «тук-тук» диеп йөрәк тибеше.* Л.Шагыйрьҗан

**ТҮГҮ** *ф.* 1) Сыек яки бөртекле нәрсәләрне савыттан кою, агызу, сибү, чәчү. *Суын түкмәс өчен, Миңлеасия бии-бии атлый. Һай аның ул атлаулары!* Г.Ахунов. *Сөтне, ачытып, чебигә ашатсалар ашаталар, чыгарып түксәләр түгәләр, әмма сатмыйлар.* М.Мәһдиев

2) Кирәкмәгән нәрсәне, чүпне чыгарып ату, берәр урынга алып барып ташлау. *Әнә берәүсе, арган атны чыбыркылый-чыбыркылый, тирес түгәргә бара.* Г.Сабитов. *--- завод артындагы чүплеккә исә канаудан ниндидер сыеклык саркып чыга, ул сыеклык өстенә кешеләр азык-төлек калдыклары чыгарып түгәләр, ә хәтәр сыеклык ул калдыкка сеңә...* М.Мәһдиев

3) Күпләп кою, агызу. *Яулап тыныч киләчәкне, Җир шарын шуышып үттек. Һәр секундта без кан түктек, Һәр минутта без кан түктек ---.* Ш.Галиев. *Яшь яңгырым түккән идем, Таңнарда төшкәч томан.* Ә.Синугыл-Куганаклы

4) *иск.* Салу, кушу, өстәү, кату. *Буранлы көн туганмын, Борыч бирсәң еламам, Борычтан яман ачымам, Шикәр түксәң төчемәм ---.* Дастан

5) *күч. шигъ.* Тарату, чәчү, сибү (нур, моң, тавыш һ.б.ш. тур.). *Алып менә тургай мулдан җир җырын күкләренә. Түгә иде моңын гүя яшь арыш төпләренә.* Р.Әхмәтҗан

6) *күч.* Эчендәге серләрен ачып салу, берәр кешегә сөйләп бирү, уйфикерләрен кеше белән уртаклашу. *Инде шактыйга сузылган моң-зар түгү һәркемне туйдырган иде булса кирәк.* Ф.Сафин. *Башкорт беркемгә дә игътибар итмәде, көне буена, юк, атналар буена җыелган әрнүен, шикләрен, кимсенүләрен дөньяга түгеп, Тәңре белән сөйләшүен белде.* Р.Зәйдулла

7) *күч.* Сарыф итү, багышлау, кую, салу (көч, вакыт һ.б.ш. тур.). *О-о, гаиләдә ир ир булсын өчен, хатын-кыз сансыз-исәпсез көч түгә!* А.Гыйләҗев. *Ояга вентиляция ясаучы умарта кортлары, тыныч хәлдәге кортларга караганда, йөз тапкыр диярлек артыграк энергия түгәләр.* Умарта кортлары

8) *күч.* Тотып бетерү, бик күп тоту. *Нью-Йорк бу эшкә күп акча түгә.* Г.Гали

**Түгеп бетерү** Барысын да түгү. *– Шлакны түгеп бетермичә, мин вахтаны кабул итмим, – диде Емельянов.* М.Юныс. *Нәфисә күңелендәге уйларын соңгы тамчысына кадәр түгеп бетерергә булды ---.* Г.Гыйльманов

**Түгеп җибәрү** Кисәк кенә, гадәттә ялгыш түгү. *Кыз суын түгеп җибәрә, егет өч бөртек тары булып чәчелеп китә.* Әкият. *Хәтта ике тапкыр ялгыш кына тәлинкәсендәге чәен дә түгеп җибәрде, мескен...* Аманулла

**Түгеп йөрү** Теләсә кайда түгү; еш кына түгү. *Сиңа ачылдым, түгеп йөрмәссең, яме!* Марс Шабаев. *Бу кадәре дә акча түгеп йөрүеңне бер дә килештермим мин, улым ---.* Р.Гаязетдин

**Түгеп калу** Түгәргә өлгерү. *Хатын --- сөйли дә сөйли. Хәтта ашыга да: ире килгәләгәнче, күңелендәген түгеп калырга ашыга сыман.* К.Тимбикова

**Түгеп килү** Шактый вакыттан бирле яки гел түгү

**Түгеп тору** Хәзерге моментта яки даими рәвештә түгү. *Казылган җирдән суны котелоклар белән түгеп торабыз.* Яңарыш

**Түгеп утыру** *к.* **түгеп тору**. *Ах-вах итеп, зар елап, канлы яшьләрен түгеп утырмады ---.* Г.Гыйльманов. *Һәр бизәген иренмичә юнып-чокып, күпме күз нурын түгеп утырган.* В.Нуриев

**ТҮГҮ-ЧӘЧҮ** *ф.* 1) Саксыз эшләп яки ялгышлык белән агучан, сибелүчән нәрсәләрне чәчү, тарату, түгү

2) *күч.* Әрәм-шәрәм итү, туздыру, саксыз тоту

**Түгеп-чәчеп бетерү** Булган бар нәрсәне ахырына кадәр түгү. *Их сез, кызлар, кызлар! Тәмәке төрә белмисез бит! Барлы-юклы әчмүшкәмне дә түгеп-чәчеп бетердегез.* А.Хәсәнов

**Түгеп-чәчеп йөрү** Теләсә кайда, һәр җирдә түгү. *Орышырга дисәң, йөгемдәге печәнне түгеп-чәчеп йөрмим бугай, иптәшләремнән дә ким эшләмим кебек, Сәләй белән Кәрим ничә йөк илтеп аударсалар, мин дә шуның кадәр үк илттем...* Г.Тавлин

**ТҮЗ** *и. диал.* 1) Үсемлекнең, кисеп яки чабып алгач, җирдән чыгып калган өлеше; төп. *Картлар сүзе – кәбестә түзе.* Әйтем

2) Елга тамагы. *Бу авыл елга түзендә утыра*

**ТҮЗӘРЛЕК** *с.* **1.** 1) Түзәргә мөмкин булган, чыдарлык дәрәҗәдәге. *Көне-*

*төне селкенми бер урында яту никадәр генә туйдырмасын, эчке сызлавы адәм түзәрлек булса, Габбани ыңгырашмады.* Ә.Галиев

2) Нык, чыдам. *Зур тизлеккә түзәрлек яңа материал һәм тиешле форма үзгәрешләре кирәк.* Ш.Галиев. --- *«кара алтын» ятмалары булган җирләрдә сейсмик нык-таза, ягъни җир тетрәүләргә түзәрлек скважиналар борауларга туры килмәгәе...* Казан утлары

3) *күч.* Уртача, ярыйсы гына, бик начар түгел. --- *ул барып кергәндә, ике-өч хатын-кыз бар иде. Икесе – түзәрлек, сүз-йомыш сыя торган хатыннар ---.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв.* Түзеп булырлык рәвештә. *Кичке пароход белән аска төшеп тә киттек. Аска төшүебезне сөйләмим, түзәрлек булды.* А.Хәсәнов

**3.** *и. мәгъ. к.* **түземлек**. *Минем түзәрлегем калмаган иде инде.* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮЗГЕСЕЗ** *с.* **1.** Түзә алмаслык дәрәҗәдәге, түзәрлек булмаган. *Адәм түзгесез эсседә фуфайкасы көйри башлагач, без аны тартып чыгарып, өстенә су койдык.* С.Сабиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Түзеп булмаслык рәвештә. *Минем гармунга өйрәнәсе килү тора-бара* **---** *кытыкланып, түзгесез кычынып йөрәккә төшә.* Ш.Маннур. *Кояш түзгесез кыздыра, үтереп эчәсе килә.* З.Мурсиев

**ТҮЗЕЛҮ** *ф. з.-сыз. к.* **түзү**. *Хәйран калам: ничек түзелгәндер! – Бер йөрәккә күпме хәсрәт ич.* Ә.Рәшит

**ТҮЗЕМ** *с.* **1.** 1) Берәр эш-хәлне сабырлык, чыдамлык белән үткәрә торган; сабыр, чыдам (кеше тур.). *Фәхри каенагага да сабыр итәргә кирәк иде инде, ир кеше бигрәк тә түзем булырга тиеш иде.* М.Гафури. *Бүтәннәрне кайгыртып та үз хәсрәтен сиздермәүче сабыр холыклы бу түзем кешенең алдына тезләнәсе [килә].* Г.Бәширов

2) Чыдам, түземле. *Сагынмый үткән сәгатем Сирәк бит, сирәк, сирәк: Мең сәгать сабыр итәргә Иң түзем йөрәк ләбаса, Реактор йөрәк кирәк.* Х.Туфан. *Суыкка түзем, чүлдәге кызулыкка да бирешми алар [алабайлар]...* Р.Мөхәммәдиев

3) Сабырлык, чыдамлык таләп итә торган. *Ни китерер? Байлык, бозыклыкмы? Әллә түзем эшме? Тырышумы?* Ә.Фәйзи

**2.** *рәв. мәгъ.* Сабыр. *Ул мине күреп елмайды, --- ботинкаларымны салганны түзем генә көтеп торды.* А.Гыйләҗев

**3.** *и. мәгъ. к.* **түземлек**. *Моңа түзеп-түзеп тә түземе төкәнгән Габделмәгыйзь абзый беркөнне әйтә моңа ---.* Ш.Маннапов. *Болай да бик каты кайгырып, эчтән сызып йөргән Хәлимәнең шуннан соң түземе шартлады.* В.Нуруллин

**ТҮЗЕМЛЕ** *с.* **1.** 1) Нык, чыдам, таушалмас. *Безнекеннән дә арзанрак, түземлерәк малны Ташаякны бер итеп эзләсәгез дә таба алмассыз!* Ә.Фәйзи

2) Төрле кыенлыкларны, авырлыкларны, күңелсезлекләрне сабырлык белән кичерә ала торган, сабыр, чыдам (кеше тур.). *Гомер буе аңа охшарга тырышачакмын. Аның кебек үз-үзен аямый торган, түземле, сабыр, тыйнак, искиткеч саф намуслы.* Ш.Рәкыйпов. *Сынаса да тормыш, сындырмады, Сынауларда булдык түземле.* Ш.Галиев

3) Чыдамлылык, сабырлык таләп итә торган. *Мондый заман эшчеләр партиясеннән --- түземле көрәш алып баруны сорый.* Г.Нигъмәти

**2.** *рәв. мәгъ.* Берәр эштә, тормышта чыдамлылык, ныклык, сабырлык күрсәтеп. *Югарыда китерелгән кайбер мисаллар Ә.Фәйзи, М.Максуд, Ә.Ерикәй кебек бер төркем язучының озак, түземле, нык һәм күп эшләүләрен күрсәтә.* М.Җәлил. *Шәһит бабай да, --- әллә гүя өметсез, рәхимсез авыруны түземле кичерә белү өчен уйлап чыгарылган бу гаҗәп тә кешелекле гадәткә тыйнак хөрмәт йөзеннәнме, актык сулышына кадәр авылдашларыннан авыруын яшерде.* З.Биишева

**ТҮЗЕМЛЕК** *и.* Берәр авырлыкны, кыен хәлне кичерүдә, эш башкаруда чыдамлык, сабырлык; түземле булу сыйфаты. *Теге шакыган кунак, түземлеген җуеп, ресторан ишеген дөбердәтергә кереште.* М.Насыйбуллин. *Әсәрләрдә, башлыча, табигать һәм кеше арасында көч сынашу; акылы, тапкырлыгы, түземлеге, физик көче аркасында кешенең җиңеп чыгуы турында сүз бара.* Л.Ихсанова

◊ **Түземлек касәсе ташу** *кит. к.* **сабыр савыты тулу**. *Түземлек касәсе тулып ташкан халык, чарасызлыктан ярдәм сорап, президент Рөстәм Хәмитовның блогына мөрәҗәгать итте.* Кызыл таң

**ТҮЗЕМЛЕЛЕК** *и. к.* **түземлек**. *Иптәш Кутуев сугышта һәрвакыт батыр һәм кыю иде. Үзенең түземлелеге, шат күңеллелеге белән башкаларга үрнәк булды.* Р.Ишморат. *Кавендиш тәҗрибәләр ясаганда гадәттән тыш осталык һәм тапкырлыкка, куйган максатына ирешү өчен түземлелек һәм сабырлыкка, кыскасы, үз сыйныфы кешеләре белән аралашкан чакта җитмәгән бөтен сыйфатларга ия булган.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**ТҮЗЕМ-САБЫРЛЫК** *җый. и.* Түземлек, чыдамлык, сабырлык. *Җимерелә каршы тору көчем – вирусларның «җанын» алырлык. Тамчы-тамчы көн дә агу эчеп, кимерелә түзем-сабырлык.* Л.Шагыйрьҗан. *Китапның якты битләреннән --- адәм баласы никадәр хасият ала, аң-зиһен туплый; рәнҗетелеп, эзәрлекләнеп һәм кимсетелеп, җан тамырлары өзлегер, шартлар хәлләргә җиткәндә, никадәр түзем-сабырлыклар таба ---.* А.Хәлим

**ТҮЗЕМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Түземлеге, сабырлыгы булмаган; сабырсыз, чыдамсыз. *Йокыга бик түземсез шул син, улым.* М.Гали. – *Бирмәсәгез, мин өлкән штурманга рапорт язам. – Син шундый түземсез кешемени?* М.Юныс

2) Сабырсызлык, чыдамсызлык белдерә торган. --- *бер-берсенә бирелгән түземсез сорауларның никадәр күп булуы үзеннән-үзе билгеле инде.* Г.Әпсәләмов. *Түземсез чырай*

**2.** *рәв. мәгъ.* Сабырсызланып, тынгысыз рәвештә. *Күрми калмагаем дип, йөрәк түземсез тибә дә тибә.* Х.Сарьян. *Киң, тигез урамның ике ягын да тутырып торган, түземсез гөрләшкән кешеләр, быргы тавышына колак салып, тып-тын калдылар.* Н.Фәттах

**ТҮЗЕМСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Сабырсыз кылану, түземсезлек билгеләре күрсәтү, түземлекне җую. *Әнә ул, тирләгән*

*пеләш башын сөртә-сөртә, түземсезләнеп, ишекле-түрле йөри.* Ш.Рәкыйпов. *Авырулар язга чыкканны, авыр кыштан котылганны түземсезләнеп көтәләр.* А.Гыйләҗев

**Түземсезләнә бару** Торган саен ныграк түземсезләнү. *Сөрген срогы ахырына якынлашкан саен, Владимир Ильич түземсезләнә бара.* Казан утлары

**Түземсезләнә башлау** Түземсезлек билгеләре күрсәтү. *Шул җирләрдәге тормышны күз алдыма китерсәм, түземсезләнә башлыйм.* М.Юныс. *Бүреген киде, түземсезләнә башлаган кунагына баш какты да, мылтыгын ачу белән җилкәсенә ташлап, чалош-полыш аска атлады.* Ә.Әминев

**Түземсезләнә төшү** Тагын да ныграк түземсезләнү; аз гына түземсезләнү

**Түземсезләнеп китү** Билгеле моменттан алып сизелерлек түземсезләнү. *Базыян җиңгине күргәч, ул тагын да ныграк түземсезләнеп китте: – Я, ни бар, җиңги? Бибеш исәнме?* З.Биишева

**Түземсезләнеп тору** Хәзерге моментта түземсезләнү

**ТҮЗЕМСЕЗЛЕК** *и.* Берәр эш, шөгыль өчен түземлек булмау яки җитмәү үзлеге, чыдамсызлык; сабырсызлык. *Йөзләгән исләр арасыннан кирәген табып, эзтабар түземсезлек белән баскычтан аска таба ыргылды.* М.Насыйбуллин. *Сынау көнен түземсезлек белән көтеп алган Азат җавабын, хәрбиләрчә килештереп, кыска тотты.* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮЗЛЕК** *и. диал.* **1.** *к.* **түз** (*1 мәгъ.*)

**2.** *с. мәгъ.* Агач төбеннән яки түмәрдән ясалган. *Түзлек умарта*

**ТҮЗҮ** *ф.* 1) Чыдау, физик һәм рухи киенлыкларга каршы тору, аларны күтәрә алу, һәртөрле авырлыкларга, интегүләргә, газапларга бирешмәү; сабыр итү. *Үтә дә кызганыч, түзеп булмас дәрәҗәдә кызганыч иде бу хәл.* Г.Ахунов. *Абынсам да түзәм, Кагылсам да түзәм, Сүнгәндә дә дөрләп кабынсам, Белеп түзәм икән: дөнья гүзәл икән, Гомерең буе җырга табынсаң...* Л.Шагыйрьҗан

2) Теләгән, уйлаган, күңелгә килгән берәр эш-гамәл яки кыланыштан тыелып калу. *Кызып әйтә идем хак сүзне, Кайчакларда дәшми түз икән.* Ш.Галиев. *Түзмәссең озак, Син дә бит Чыгарсың бу юлларга...* Ф.Гыйззәтуллина

3) Тискәре күренешнең булуына ис китмәү, аңа ризасызлык белдермәү, каршылык күрсәтмәү. *Ниһаять, хәзәрләрнең эзәрлекләп торуына түзә алмыйча, болгарларның өченче төркеме, Кубрат ханның өченче улы Котрак җитәкчелегендә, Кубань һәм Дон буйларыннан кузгалып, озын юл үтеп, Идел һәм Чулман буйларындагы урман-далалар куенына килеп сыена.* М.Мәхмүтов. *Болар Мисырдагы коллыкка түзә алмыйча чыгып киткән еврейлар булганнар.* Робинзон эзләреннән

4) Зыян китерә, тискәре йогынты ясый торган тышкы тәэсирләрдән таушалмау, тузмау, үзенең элекке сыйфатларын, үзлекләрен югалтмау; чыдау. *Сталинградта, Курск тирәсендә таш чыдамады, тимер түзмәде, ә совет солдаты күкрәк киереп алга баруында булды.* Ш.Рәкыйпов. *Күн иярләр түзми шәп атларга, Йөрәк ничек түзсен еракларда?!* Зөлфәт

5) Берәр таләпне, шартның үтәлүен һ.б.ш. кичектереп тору, көтү. *Бурычны бераз түз әле!*

◊ **Түзәр әмәл калмау** Салкын, эссе, авырлык, арганлык һ.б.ш. чигенә җитү, артык түзә алмау. *Җанга тиде тәмам [теге мөртәт], түзәр әмәлем калмады.* М.Хәбибуллин. *Атның шаянлыгына, арт сикертеп чапкынлавына, кыланмышларына түзәр әмәл калмагач, томтык та җылы абзарга чыгардык үзен.* Шәһри Казан. **Түзәр әмәл юк** *к.* **түзәр әмәл калмау**. **Түзәр хәл калмау** Түземлек бетү, сабырлык җитмәү. *Башкайларым катты инде, Калмады түзәр хәлем.* Атнабай. *Төн урталарында, инде тәмам башлары миңгерәп, түзәр хәлләре калмагач, Ләйсән ишеккә атылды.* М.Маликова. *Түзәр хәле калмагач, бәк кача-поса йортның тәрәзәсе янына килде, үрелеп эчкә карады.* М.Юныс. **Түзәр хәл юк** *к.* **түзәр әмәл юк**. --- *Зәмзәмбикә килеп керде. Керү белән: – Фу-у, билләһи генәм! Түзәр хәлләр юк... – дип, салкыннан зарланган булды.* М.Хәсәнов. *Коточкыч авыртулардан гаҗиз булып, якын-тирәдәгеләргә болай дип тә әйтә [Ф.Әмирхан]: «Үләсем бер дә килмәсә дә, бу авыртуларга түзәр хәлем юк, миңа үлем теләгез».* Р.Әмирхан. **Түзәр чама калмау** *к.* **түзәр әмәл калмау**. *Үлеп яраткан кызым бар, җан юлдашым Әзизәм бар, түзәр чамам калмады, саргайдым, Якуп абзый, ипидер...* Э.Касыймов. **Түзәр чама юк** *к.* **түзәр әмәл юк**. **Түз генә** *к.* **түзеп кенә тор**. *Өерләре белән ташландылар үзенә. Түз генә! Җыелыш кебек нәрсә дә ясап алдылар. Тетмәсен теттеләр Хәдичәнең.* М.Хәсәнов. **Түзеп кара** *к.* **түзеп кенә тор**. *Минә шуңа түзеп кара инде! Йөрәгең-җаның булса, ничек түзмәк кирәк?!* Г.Гыйльманов. **Түзеп кенә тор** Берәр кешегә карата мөгамәләдәге сүзнең яки гамәлнең, гадәттә орышу, кыйнау һ.б.ш. көчле, күңелгә авыр булуын белдерә. --- *[Әбием мине]--- кыздырырга тотынды, түзеп кенә тор!* М.Фәйзи. *Хәзер инде түзеп кенә тор, абзыкай. Үз дигәнемне эшләмәсәм, исемем Әмир булмасын!* Җ.Дәрзаман. **Түзсәң түз** *к.* **түзеп кенә тор**

**Түзеп йөрү** Күптәннән бирле түзү, шактый вакыт түзү. *Күңелендә туган авыр, караңгы уйларын бераз вакыт әйтмичә түзеп йөрсә дә, Сания бер дә бер көнне Нәфисәгә бөтен күңелен ачты.* Г.Гыйльманов. *Үзем яраткан кешене очратырмын дип еллар буе хыялланып һәм түзеп йөргән Даниялның Әлфинурны һич тә югалтасы килми иде.* З.Фәйзи

**Түзеп калу** Үз-үзен тыю, берәр гамәл кылу турындагы фикереннән ваз кичү. *Бу сүзләрне ишеткәннән соң, Сабираның үзенә нинди кабахәтлек кылганын искә алып, йөрәгеннән әрнетерлек итеп әйтәсе килсә дә, түзеп калды.* З.Фәйзи. *Зөфәр, күңелендә ургылган шатлыктан, чак ура кычкырмый түзеп калды.* Ә.Галиев

**Түзеп тору** Билгеле вакыт дәвамында түзү. *Моңарчы түзеп торганыбызга рәхмәт әйт тә, эшеңнән азат итүләрен сорап, колхозчыларның гомуми җыелышы исеменә гариза яз!* В.Нуруллин. *Өйләдән соң каравыл өе тирәсендә бер төркем ирләр җыелып торган җиргә килгән Назыйм түзеп тора алмаган, шапырынырга тотынган.* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮК** *и.* 1) Мамык, йон, тукыма кебекләрнең тыгызлап уралган зур төргәге; тюк

2) Печән, салам кебекләрнең прессланган, тыгызланган бәйләме. *Әгерҗе районында крестьян-фермер хуҗалыгында 400 түк печән янган.* Безнең гәҗит

**ТҮКӘЛӘ** *и. ирк. диал.* Кечкенә ир бала

**ТҮКӘНЕМ** *и. диал.* Кечкенә балаларга карата иркәләп әйтелә торган эндәшү сүзе; нәнием, үскәнем

**ТҮКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Кечкенә балта, чүкеч кебекләр белән җиңелчә бәргәләп, суккалап, чапкалап, нечкә саңгырау тавыш чыгару, түк-түк итү

**Түкелдәп тору** Бертуктаусыз түкелдәү; хәзерге моментта түкелдәү

**ТҮКЛӘ́Ү** *ф.* Түкләргә бәйләү (печән, салам кебекләрне). *Алар фураж өелгән җиргә баргач та, түкләнгән печән өемнәре арасына хәл алырга утырдылар.* М.Гали

**Түкләп йөрү** Рәттән түкләү

**Түкләп кую** Алдан ук түкләп, әзер хәлгә китерү

**Түкләп тору** Даими түкләү; хәзерге моментта түкләү

**Түкләп чыгу** Барысын да, башыннан ахырына кадәр түкләү

**Түкли башлау** Түкләргә керешү

**ТҮКМӘН** *и.* 1) Зур агач савыт. *Базда – батман, түрдә – түкмән.* Табышмак

2) *күч. гади с.* Аңгыра кеше. *Тик тор, түкмән, анда барып, авыртмас башка тимер казык алып кайтырга телисеңме?* Җ.Вәлиди

**ТҮКМӘ́-ТҮК** *рәв. диал.* Төп-төгәл, нәкъ туры китереп; чамалаганча. *Акчам түкмә-түк булды, артып та калмады, җитми дә калмады.* К.Насыйри

**ТҮ́КМИ-ЧӘЧМИ** *рәв.* 1) Берсен дә калдырмыйча, югалтуларсыз. *Солылар, бер-берсенә тотынышып, стена кебек утыра. Игенче шуларның бөртеген дә түкми-чәчми җыеп алырга ашыга.* К.Тәхау

2) *күч.* Тулысынча, бөтен килеш. *Кырык кул аша үтеп, таушалып, буялып, укылып беткән булса да, өйдәгеләрнең күңел җылысын түкми-чәчми китереп җиткергән иде ул [хат].* И.Гази. *Ә Сез, Рабига апа, Фәрит абый, моңлы көйләребезне халыкка түкми-чәчми ирештерүче, үзенчәлекле итеп башкаручы җырчы, моң осталарыбыз.* Мәдәни җомга

3) Бернәрсәне яшермичә, туп-туры, дөп-дөрес. *Хафиз барысын да түкми-чәчми сөйләп биргәч, Биккол беркавым дәшми-тынмый утырды.* М.Хәбибуллин. *Хисләремне, түкми-чәчми, шигъри телгә күчердем мин...* Л.Шагыйрьҗан

4) Бәйнә-бәйнә, бөтен ваклыклары һәм нечкәлекләре белән, тәфсилләп, җентекләп. *Рәйсә ничек өйләнүегез турында да, каһәрле тормышыгыз турында да түкми-чәчми сөйләде.* Г.Тавлин. --- *аңа баш хирург Янис Августович, бөртеген дә түкми-чәчми, Айтуганновның ачы язмышы турында сөйләгән булган.* Җ.Тәрҗеманов

5) *күч.* Бик пөхтәләп, берәмтекләп, җиренә җиткереп. *Махсус сорап алган җәймәне җәеп, ястү намазын түкми-чәчми укыдым.* Ш.Камал. *Алар эшне һич ашыкмый, түкми-чәчми тырышыптырышып эшлиләр.* З.Бәшири

**ТҮК-ТҮК** *иярт.* Агач яки тимер кебек каты өслеккә кечкенә нәрсә белән җиңелчә бәргәндә, басканда, чапканда чыккан тавышны белдерә. *Аның биек үкчәле туфлиләре белән түк-түк басуы Зәһидка ишетелгәндәй булды.* А.Расих

**ТҮК-ТҮК ИТҮ** *ф. к.* **түкелдәү**

**ТҮЛ** *и.* 1) Ана кош-кортларның, бигрәк тә тавыкларның, күкәйлегендә кечкенә йомырка яралгылары, вак кына түгәрәк сарылар; орлыклар. *Әтәчләр язга кычкыра башладылар, күкәйгә түл җыя торган тавыкларның кикрикләре кызарып китте.* Ф.Хөсни. *Әйтәм бит, юкка гына кытаклыйсың син. Миңа ич түлнең әсәре дә юк.* Г.Галиев

2) *сөйл.* Кеше яки хайван тәнендәге май. *Түзгән түл җыйган.* Мәкаль. *Ә миңа җәй көне, түл җыйган үрдәк кебек, алар авылда шактый хәлләнеп килгән.* С.Поварисов

3) *сөйл.* Байлык, мал. *Борчылма, монда да әкренләп түл җыярсың әле, совхозыңны күтәрерсең.* А.Расих

4) *сөйл.* Белем, гыйлем; тәҗрибә һәм акыл. *Ләйләгәл инде түлне төрле мәктәптә укып җыйган.* М.Мәһдиев. *Туган якларымда түл җыям да Казаныма кайтып язамын.* Ф.Яруллин

**ТҮЛӘК** *и.* Штраф. *Мин сине Казан белән килештерермен, сезгә түләк түләргә боерырмын.* Һ.Атласи. *Котылырга телим мин аңардан – риза, риза бөтен түләккә... Ә ул миннән сиңа багышланган шигырьләтә генә түләтә.* Р.Харис

**ТҮЛӘМ** *и. к.* **түләү** II. *Бүләк чыгымы, җир түләме, морҗа салымы алмасыннар. Эчемлек, терлек азыгы түләтмәсеннәр.* Һ.Атласи. *Бик күп контрибуция (җиңелү түләме) түләп, Казанга Мещера җирләрен кайтарып, Василий II Мәскәүгә китә.* Т.Кәримов

**ТҮЛӘМӘ** *и.* Ешрак хайваннарда, кайчакта кешеләрдә дә була торган йогышлы авыру; яман шеш, яман кычу; *русчасы:* **сибирская язва**. *Алар [икекапатлылар] төрле йогышлы авырулар тарата алалар, мәсәлән, йокы авыруы һәм бизгәкне, корсак тифы һәм дизентерияне, түләмә һәм чуманы, проказа һәм туляремияне.* Биология. *Аларның [авыруларның] иң куркынычлары түләмә, чума, рожа, маңка авыруы (сап), котыру авыруы булган.* Татарстанда терлекчелек

**ТҮЛӘМӘ ҖИЛӘГЕ** *и. бот. к.* **карга борыны, карга күзе**

**ТҮЛӘМӘЛЕ** *с.* Түләмә йоктыра торган; түләмә белән авырый торган

**ТҮЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **түләү**. *Мин монда тирләп-пешеп синең эшеңне җайлап йөрим, ә син әле тагын акча да түләтмәкче!* М.Маликова. *Куштан ул белә хак түләтә: Сарайлар салдырта бүләккә.* Ф.Гыйззәтуллина

2) Китерелгән зыянны капларга мәҗбүр итү. *Аннан башка да борчулы вакытыбыз. Миңа ат түләтәбез дип торалар.* М.Мәһдиев. *Ахырда, үлгән айгырның хакын Әхмәттән түләтергә һәм үзен иртәгәдән үк эшкә чыгарга мәҗбүр итәргә, диган карар кабул ителде.* Ф.Мансуров

3) *күч.* Үч алу

**Түләтә башлау** Түләтергә тотыну. *Җир-калаларын гына яулап калмадылар, империя кадәр империядән ясак түләтә башладылар.* М.Хәбибуллин

**Түләтеп бетерү** Тулысынча түләтү

**Түләтеп тору** Даими рәвештә түләргә мәҗбүр итү, озак вакыт дәвамында түләтү. *Бу заман Казан Мәскәүне буйсындырып, куркытып, ясак түләтеп торучы бик тә куәтле ил була.* Р.Батулла

**ТҮЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Сатып алынган яки файдаланылган әйбер, башкарылган эш яки гомумән нинди дә булса башка берәр хезмәт өчен акча яисә шуңа бәрабәр булырлык берәр нәрсә бирү. *Безгә бит, вак тиредән бер бүрек эче җыйганга – ике тиен, --- бүрек тышын кисеп теккән өчен, бары өч тиен түлиләр.* М.Гали. *Юк, агайне, язучылык өчен акча түләмиләр. Язган өчен генә – анда да, басылып чыкканы өчен генә түлиләр.* М.Мәһдиев

2) Теге яки бу йөкләмәләрне үтәү. *Ит, бәрәңге заданиеләрен аерым хуҗалыклар күбрәк түли иде.* М.Мәһдиев. *Өздем инде мин колхоз белән араны... Ссуданы түләп кайттым.* К.Кәримов

3) Бурычны кайтару, бирү. *Житмеш – җимеш кояр чак, Бар чаклысын җыяр чак. --- Эшләмәгән эшләрне – Бурычларны түләр чак.* Ш.Галиев. *Үзеңнекеләрме?! Бурыч түлисе бар дип, бирәрсен рәнҗетмәдеңме? Безгә харам мал килешми.* К.Кәримов

4) Китерелгән зарар, зыянның хакын каплау, кире кайтару. *Әле сез минем бер караңгыдан икенче караңгыга эшләгән белән ат түләмәкчемени!* М.Мәһдиев. *Миңа мораль зыян китергән өчен, Гарифуллин Марат белән Гарифуллина Галиябану компенсация түләргә тиешләр дип саныйм.* Т.Миңнуллин

5) Бер яктан килгән зарар яки чыгымны икенче яктан килгән файда белән каплау, кире кайтару, аклау. *Аннан соң хуҗа хатынга: – Егетне сыйла, сөтен-маен кызганма, правление хакын түләр, – дип кисәтте дә китеп тә барды...* Н.Дәүли. *Моннан тыш Касимов Һиндстан җирендәге рус әсирләрен хак түләп булса да азат итәргә --- тиеш була.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Җавап бирү, кайтару. *Пар күгәрчен кебек гөрләшкәндә, Мәхәббәткә нигә күләгә; Керсез сөюемә, язгы гөлем, Авыр сүзләр белән түләмә.* Ә.Рәшитов. *Синең яратуыңа мин ни белән булса да түләргә тиеш.* Т.Миңнуллин

7) *күч.* Элекке эшләренең җәзасын алу, элекке бозык, начар эшләре өчен җавап тоту. *Аларның елга аръягындагы җир-сулары, дала-тугайлары – орыш кырында кан койган угланым, алыпларыбыз өчен түләү булыр.* М.Хәбибуллин. *Барысы да бер юлы аңлашыла, барысы өчен дә түләргә кирәк... Һәм түләделәр дә.--- Әйе, дога белән каргышка пәрдә юк шул.* Н.Гариф

**Түләп бару** Регуляр рәвештә, рәттән һәрберсен түләү. *Шәмгун карт ул налогны, страховой акчасын һәм башка шуның кебек җыемнарны үз вакытында түләп барырга ярата.* А.Шамов

**Түләп бетерү** Түләнергә тиешле сумманы тулысынча каплау, түләү эшен тәмамлау. *Мөгаен, каравылчыдыр. --- Электереп алса, беттеләр: штрафын җәй буена түләп бетерә алмассың...* Г.Ахунов

**Түләп йөрү** Һәркемгә яки күп кешегә түләү, күп җирдә түләү. *Бу юлы [Мәхмүт], бүлмә саен кереп, кешеләргә әҗәтен түләп йөргән.* К.Тимбикова

**Түләп килү** Билгеле вакыттан алып, регуляр рәвештә түләү. *Башкалар итне кырык килограмм түләгәндә, Чулак Абдул алтмышны түләп килде.* М.Мәһдиев

**Түләп кую** Алдан түләү. *Бу – алдан ук планлаштырылган, акчасы түләп куелган сәфәр.* Р.Мөхәммәдиев. *...Икенче көнне Илһам прокат бүлегеннән кечкенә генә суыткыч алып кайтты. Бәясен бер елга алдан түләп куйды.* Х.Ширмән

**Түләп тору** Гел, даими рәвештә түләү, билгеле вакыт аралыгында түләү эшен башкару. *Эшләр шушылайга ук китәрен чамалаган булса, --- Хәнәфи ул Табак битне шатырдатып торып судка бирер иде дә аңа гомер буе түләп тора торган иттерер иде.* В.Нуруллин

**Түләп яту** *к.* **түләп тору**. *Мәктәптә укыганда мактанып йөргән иде, ди. Хәзер әтисе акчасыннан комсомол взносы түләп ята, ди.* Т.Миңнуллин

**ТҮЛӘ́Ү** II *и.* 1) Берәр нәрсә сатып алган яки файдаланган өчен бирелгән акча яисә әйбер; хак, бәя. *Менә сезгә ябык веранда, түләү-фәлән сорамыйм. Торыгыз.* Г.Тавлин

2) Һәртөрле салым, җыем, налог. *Үземә генә бик кыенга туры килә, түлисе түләүләрем дә күп ич әле.* В.Нуруллин. *Товарларны бу корабльләрдә Урта диңгез аша алып чыккан өчен, венециялеләр тагын зур түләү таләп итәләр.* Робинзон эзләреннән

3) Хезмәт хакы. *Узган ел табыш зур булды. Җәй иплә килде. Өстәмә түләүгә генә уникә пот бал алдым.* М.Мәһдиев

4) Түләк, штраф, йолым

**ТҮЛӘ́Ү** III *ф.* Тудыру, бала табу. *Әнкәй бәби түләгән дә Ак яулыкка [биләгән].* Җыр

**ТҮЛӘҮЛЕ** *с.* 1) Акчалата түләү шарты белән башкарыла яки хезмәт күрсәтә торган. *Инде түләүле концертларга качып-посып билетсыз кергәндә, элеккечә клуб ишегеннән дә чыгарып ата алмаслар.* М.Мәһдиев. *«Чуарбаш», Болакның уң ягына борылып, түләүле поликлиника ишеге төбендә туктала.* М.Насыйбуллин

2) Ялланган, яллаулы, акчага, хезмәт хакына эшли торган. *[Империализмның] түләүле агентлары мораль яктан нык булмаган бәндәләрне эзли.* Г.Әпсәләмов

3) Акча, хезмәт хакы түләнә торган. *Биш ай түләүле отпыскада булды.* Х.Сарьян. --- *Хәйруллин, аспирантурада йөреп карап, үзеннән фән әһеле чыкмасын вакытында аңлап, түләүле һәм мактаулы иҗтимагый эшкә күчә.* Т.Галиуллин

**ТҮЛӘҮСЕЗ** *с.* **1.** 1) Түләмичә алырга, файдаланырга мөмкин булган, бушлай бирелә торган, тиген. *Түләүсез малның кадере булмый.* Мәкаль. *Гидроэлектростанция корылган елга агып бетмәслек булганга, гидростанция дә түләүсез ягулык белән тәэмин ителеп тора.* Дөньяда ниләр бар

2) Хезмәт хакы түләнми торган; бушлай эшләнә торган. --- *мин кемнәрнеңдер түләүсез хезмәтчесе булудан гарык.* Г.Тавлин. *Ял итәм! Тагын бер айга түләүсез ялга кудылар безне!* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Акча сорамыйча, түләү таләп итмичә. *Концерт бирдең бер түләүсез-нисез, синең җырың яуны җиңеште. Сандугачым, моңа, бер уйласаң, бездән сиңа орден тиешле.* Р.Әхмәтҗан

**ТҮЛЕРҮ** *ф. диал.* Йокымсырау. *Ул арган, күрәсең, түлереп утыра.* Безнең юл

**ТҮЛЛЕ** *с.* 1) Түле булган, түл җыйган; симез, май туплаган

2) *күч.* Хәлле, бай. *Бөтен юмартлыгы ачылган чак, Түлле чагы хозур җиремнең. Көннән муллык агып торыр вакыт, Җәлләмәсәң хәләл тиреңне.* И.Киньябулатов

**ТҮЛТ** *иярт.* Берәр сыеклыкка вак кына нәрсә килеп төшкәндә чыга торган тавышны белдерә; былт

**ТҮ́ЛТ ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару

◊ **Түлт итеп** Кинәт килеп чыгу, пәйда булу (берәр кеше яки кечерәк нәрсә тур.)

**ТҮМ-** *кис.* Кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Агачта пеште чия. Түм-түгәрәк, Матур чия! Куе кызыл, Зур чия!* Р.Мингалим

**ТҮМӘР** *и.* 1) Бүкән, тумран, төп. *Рәхимҗан бабай тимер чөй белән пеше карама түмәрләрен ярырга азаплана.* А.Гыйләҗев. --- *башны рундукка төртеп, аякларны переборкага терәп, түмәргә кысылган чөй шикелле берегеп яттык.* М.Юныс

2) Урындык итеп кулланыла торган агач төбе яки шуңа охшаш нәрсә. *Сарман углан әкрен генә түмәреннән күтәрелде һәм шушы яман сүзләрне әйткән ак сакаллы картка текәлеп карады, әмма шундук кире урынына утырды.* М.Хәбибуллин

3) *күч. тирг.* Аңгыра, юньсез кеше. *– Түмәр! Томана! – дип кычкырды да, җәһәт килеп, мундирның дүрт кесәсен дә умырып төшерде* [майор]. М.Хафизов. *Ә син – түмәр, утын агачы. Йөрепйөреп юньле кыз таба алмагач, миңа килеп өйләнгән булдың.* Казан утлары

**ТҮМӘРКӘ** *и. к.* **түмәр**. *Өй нигезе буенда каен түмәркәсе тырпаеп тора.* Г.Ахунов. *Хәкимҗан үзе, тунын салып, теге хатыннар яра алмаган берничә түмәркәне ярып ташлады.* М.Мәһдиев

**ТҮМГӘК** *и.* 1) Сазлык яки иңкү җирдә үлән яисә мүк белән капланган вак-вак калкулыкларның берсе. *Итек табаннары батып тора, сазлык түмгәгендәге шикелле, тигезлек саклавы читен.* Ә.Гаффар. *Һәммәсе дә шигырь аңа, Һәммәсе – галибанә: Капка астыннан өргән эт, Түмгәктәге бүдәнә...* Зөлфәт

2) Тигез җирдә калкыбрак торган урын, бик кечкенә калкулык. *Алдыңдагы чүлмәккә карап, аяк астындагы түмгәккә абынма.* Мәкаль. *Баштарак ни үзгәргәнен дә аңламады, балачактан һәр борылышка, һәр түмгәккә күнеккән күз бүген ятсынып, инешне кызганып, боегып калды.* А.Гыйләҗев

3) Зур оеш туфрак яки кар, кантар. *Караңгыда клубка барганда, хуҗаның алдан юл сабуы, аяк астындагы һәр күлдәвек, һәр түмгәк хакында искәртеп куюы, инде ярты төн узуга карамастан мунча өлгертүләре дә истә.* Т.Әйди. *Аяк астындагы түмгәк бер бадьян алма сыман чәчрәп-таралып китмәгән булсамы...* Р.Мөхәммәдиев

4) Агач төбе. *Балта чапканчы, түмгәк ял итә.* Мәкаль. *Чыннан да, Борһанны соңгы вакытта гел ялгызын гына күрәләр. Күбрәк аның зират артындагы яр өстендә түмгәк кебек ялгыз утыруын күрәләр.* М.Хәсәнов

5) Кырмыска оясы. *Очтым гына кырмыска түмгәкләре өстеннән.* Ф.Яруллин. *Җитте, чапкан печәнне җыеп, төяп тормасаң, өстеңә түмгәктән кырмыска китереп сибәм!* З.Фәйзи. *Түмгәк кырмыскаларының бәйрәм иткәнен сыңар күзле карт карап тормады, карашын тагын дулкыннарга күчерде.* Р.Зәйдулла

6) *күч.* Тормышта була торган һәртөрле авырлыклар, киртәләр, тоткарлыклар. *Тормыш түмгәкләрен без икебез Яшьлек белән бергә атладык.* Ә.Ерикәй. *Һәр адымда абынмас өчен, юлдагы түмгәкләрне күрү өчен, рухи офыкларыбызның ачык булуы зарур.* Ә.Рәшитов

**ТҮМГӘ́ККИСКЕЧ** *и.* Түмгәкле җирне тигезләү өчен махсус сабан

**ТҮМГӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Түмгәк формасы алу, түмгәк хасил итү, түмгәккә әйләнү

2) Түмгәкләр (*1 мәгъ.*) белән каплану

**Түмгәкләнеп бетү** Тулысынча түмгәкләнү. *Болыныгыз сазланган, түмгәкләнеп беткән.* Атака

**Түмгәкләнеп тору** Түмгәк формасында булу, түмгәк-түмгәк булып күренү

**ТҮМГӘКЛЕ** *с.* Түмгәкләр (*1 мәгъ.*) белән капланган, тигезсез. *Себернең түмгәкле сазлары, тайга урманнары арасыннан безнең заманда бик күп галимнәр, инженерлар, педагоглар, йөзләрчә партия һәм совет эшлеклеләре күтәрелеп чыкты.* Г.Бәширов. *Бу чикнең бер ягында җир шома, такыр һәм йөрер өчен уңайлы, икенчесендә түмгәкле, уңайсыз һәм анда алай тиз йөрерлек түгел, ди.* Кызыклы физика

**ТҮМГӘКЛЕК** *с.* **1.** Түмгәкләр (*1 мәгъ.*) белән капланган. *Малай чагында ялanаяк каз көткән, бозау көтеп йөргән түмгәклек урыннарга күз салсаң, анда да үзгәреш.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* Түмгәкләр (*1 мәгъ.*) белән капланган урын. *[Чишмәнең] тирә-ягы гел түмгәклек кенә.* Ш.Маннур. *[Каракларны] түмгәклектә колхоз бәрәңгеләрен казып ятканда эләктердек.* К.Нәҗми

**ТҮМГӘЛӘК** *и. диал.* Божра, түгәрәк

**ТҮМРӘН** *и. диал. к.* **тумран**. --- *гаиләнең асылына шайтан хуҗа булып алганда, «ир-баш» кәбестә күчәненә әйләнә. Дошман ирдән дошман хатын утын түмрәне ясый.* А.Гыйләҗев

**ТҮН** I *и. иск.* Арт, кире як. *Бу дөнья – җам, төбендә түн икәндер, Бер ай чәчәктә син, унбер ай – тикәндә.* Котб. *Үнәре үргә тарта, Арт саны түнгә тарта.* Әйтем

**ТҮН** II *и. рус махс.* 1) Балык тоту елымы. *Бөтен әйберне, көймәләрне боз өстенә төшереп куйдык. Төнләп түн салырга дип торабыз.* Ф.Сәйфи-Казанлы

2) Елым белән балык тоту эше. *Әстерханда 1910 нчы елларда мин язгы балык түненә яллandым.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ТҮНГӘК** *и. диал. к.* **түмгәк**. *Башы түнгәк, үзе күм-күмгәк.* Табышмак. *Аюдан курыккан, түнгәккә эләккән.* Мәкаль

**ТҮНГӘЛӘК** *и. диал. к.* **түмгәләк**. *«Кантимер» [сүзенең] – иң ахырында гарәпчә «м»не аңлаткан кечкенә түнгәләк һәм «р» өтере [куела].* С.Сөләйманова

**ТҮНДӘК** *и.* 1) *диал. к.* **түмгәк**. *Менә шулай тигез генә, тыныч кына эшләп барганда, малайның менгән аты түндәккә абынды ---.* Г.Ибраһимов

2) Бүкән

3) *күч. гади с. тирг.* Аңгыра кеше. *Басарый түндәкнең әтәчләнүе турында мин хәзер берни дә әйтмим.* Т.Гыйззәт

4) Уртада утырган өч бала тирәсендә түгәрәк әйләнеп йөрүдән гыйбарәт балалар уены

**ТҮНДЕ́К АЛЫШ** *и. к.* **түндәк** (*4 мәгъ.*). *Кыз балалар --- «түндек алыш», «киртәң бир» һәм «куыш» уйнарга тотыналар.* Ш.Әхмәдиев

**ТҮНДЕРБАШ** *и. бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан озын сабаклары кызыл таплар белән капланган, дару үләне буларак та файдаланыла торган агулы икееллык үлән үсемлек; елан көпшәсе; *русчасы:* **болиголов**. *Түндербаш алколоидлары организмга кураре һәм никотин агулары кебек тәэсир ясыйлар.* Агулы үсемлекләр. *Тимгелле түндербаш ташландык җирләрдә, чүплекләрдә очрый, яфракларын ышкыганда, аннан тычкан исе килә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ТҮНДЕРҮ** *ф.* 1) Кире кайтару, бору; дүндерү. *Әхмәт атасына хакыйкать хәлен аңлатырга тырышып карады, --- ләкин боларның берсе дә хәзрәтне үз фикереннән түндерә алмады.* Ф.Әмирхан. *Күрәсең, моңыбыздагы ислам аһәңе күңелләребезне кыйблага түндерә...* Р.Зарипов

2) Берәр якка таба бөгү, ию, кыйшайту. *Самохин, озын гәүдәсен алга түндереп, украин мыегын парторгка [якынайтты].* Совет әдәбияты

3) *диал.* Аудару, егу, әйләндереп салу

4) *күч.* Уйлау, фикер йөртү сәләтен бетерү, аек акыл белән эш итүгә комачаулау, башны әйләндерү. *– Бу – алкашларны түндерә торган нефть суы түгел, матурым, импортный шампански! Моның бер зыяны да юк: шаулап торганда эчеп җибәр, әйдә! – диде Сабира коры гына.* З.Фәйзи

**Түндереп җибәрү** Кисәк түндерү

**Түндереп кую** Түнгән хәлгә китерү

**ТҮНЕШ** *с. диал.* 1) Кеше мактаганга яклanучан, үзсенүчән. *Бигрәк түнеш кеше*

2) Кыланчык. *Түнеш кыз*

**ТҮНЕШЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Мактагач яклану, үзсенү

2) Кылану, кыланчыклану. *Түнешләнмә әле, тик тор!*

**ТҮНКӘРЕШ** *и. диал.* Үзгәреш, әверелеш. *ТАПП члены булгач, синнән көттек, абзый, Үзгәреш! Алай-болай бер дә кыймылдау юк, ничек соң, ә, Башланмыймы башта түнкәреш?* Атака

**ТҮНКӘРТҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **түнтәрү**

2) Эчендәгесен чыгарып салу, сөйләү, әйтү. *[Басыйр], батырлыгын җыеп, әйтер сүзен берьюлы үзе түнкәртеп ташлады.* А.Расих

**ТҮНКӘРҮ** *ф.* 1) *к.* **түнтәрү** (*1, 2 мәгъ.*). *[Балның] болай да кимен куймыйбыз, --- кичә байкайларда бер мичкәсен түнкәрдек.* А.Әхмәт

2) Берәр якка кыйшайту; түбәнгә таба юнәлтү. *Егылганны екма, Түнгәнне түнкәрмә.* Мәкаль. *Кара гына күзең, ай, түнкәреп, Ник моңландың караганда.* К.Тинчурин

**Түнкәреп җибәрү** Кисәк түнкәрү

**Түнкәреп кую** *к.* **түнкәреп җибәрү**

**ТҮНКӘЮ** *ф. диал.* 1) Түнү, берәр якка аву, кыйшаю. *Безнең һөнәрчеләребез Гыйззинең алга түнкәйгән иске өендә утыралар.* Ф.Хөсни

2) Яту. *Микулай идәндә күшәп яткан яңа туган бозау янына түнкәйде.* Р.Бәшәр

**Түнкәеп бетү** Бөтенләй түнкәю

**Түнкәеп калу** Түнкәеп, шул хәлен үзгәртмәү. *Кайсы берсе, хәлсезлектән тора алмый, агач төбендә түнкәеп кала.* Н.Хәсәнов

**Түнкәеп китү** Кисәк түнкәю

**Түнкәеп тору** Түнкәйгән булып күренү

**ТҮНКЕЛҮ** *ф. диал.* Аву, егылу. *Дошманнар ишетсә, түнкелә, Дус егетләр ишетсә, сөенә.* Җыр

**ТҮНТӘРГЕЧ** *и. тех.* Вагонеткага һ.б.ш. төялгән бөртекле, вак кисәклärдән торган йөкне аудару, бушату өчен махсус җайланма; *русчасы:* **опрокидыватель**

**ТҮНТӘРЕЛЕШ** *и.* Инкыйлаб, революция. *--- алар 1993 елның көзендә яңа контрреволюцион түнтәрелеш ясадылар: халык сайлап куйган Дәүләт Думасын туплардан аттырып куып тараттылар.* Ә.Борһанов. *Октябрь түнтәрелешен үз җилкәләрендә татыган әби-бабаларыбыз безгә ни дияр?* Татарстан яшьләре

**ТҮНТӘРЕШ** *и. к.* **түнтәрелеш**. *Ике сугыш – дөнья күләмендә... Түнтәрешләр дисәң... бихисап: Язмышларны төйде килеләрдә Тормыш атлы усал зур кисап.* Ә.Рәшит. *Русиянең архивларын туксанынчы еллардагы түнтәрештә сатып бетерделәр.* М.Юныс

**ТҮНТӘРМӘ** *и.* Балга киндер орлыгын туглап ясалган ашамлык. *Түнтәрмә ашау*

**ТҮНТӘРҮ** *ф.* 1) *сөйл.* Берәр нәрсәне аудару. *Ир, чынласа, тауны түнтәрә.* Мәкаль. *Төн тудыра – түнтәрә, Көн килә дә күтәрә.* Табышмак. *Бу кыйшайган хәерче алачыгын да төртеп түнтәрергә вакыт. Яңа өй салырбыз.* Р.Төхфәтуллин

2) Әйләндерү. *Аксак сарыкның авызына Җил түнтәргән түңгәләк төшәр.* Мәкаль

3) *сөйл.* Берәр якка юнәлтү, кыйшайту; түбәнгә таба юнәлтү. *Түгәрәк яулык текtem мин, Түгәрәк күзләрем түнтәреп.* Җыр

4) *сөйл.* Берәр нәрсәне икенче бер рәвешкә, төргә әверелдерү, икенче бер рәвешкә кертү. *Унган кеше тауны ташка түнтәрә.* Мәкаль

5) Икенче рәвешкә керү, башкага әверелү, башка форма алу, үзгәрү. *Син үсеп җиткәнче, комбайн кырыкка түнтәрер әле. Аны ел саен үзгәртеп торалар.* Г.Галиев

6) *күч. гади с.* Берәр төрле эш башкару. *Ат белән ни эш түнтәрмәк була икән [ул], белештегезме?* А.Тимергалин

7) *күч.* Берәр төрле эчемлекне, гадәттә исерткечне, эчеп җибәрү. *Беренче рюмкаларны түнтәргәннән соң ук, Ваня дөньясын онытa.* М.Насыйбуллин. *Шулай да Тимер Буга кайберәүләр кебек исереп --- утырмады, елкы итен бүсеп, куйныкын капкалап, ике аяк кымызны түнтәрде дә Тәңре күзенә чыкты.* Р.Зәйдулла

**Түнтәреп җибәрү** Кисәк түнтәрү

**Түнтәреп кую** *к.* **түнтәреп җибәрү**. *Шик-шөбһәләрегез тәмам таралсын өчен, тагын түнтәреп куегыз әле...* Б.Камалов. *Шулай диде дә Әдип рюмкасындагы эчемлекне түнтәреп куйды, шоколадның бер шакмагын сындырып авызына капты.* Л.Лерон

**ТҮНТӘЮ** *ф. диал.* 1) Берәр якка аву, кыйшаю, түнү. *Әнвәр бер җирдә*

*чирәмгә түнтәеп йоклап китте.* Х.Камалов

2) Тырпаю, кабару. *[Әти] пружиналары түнтәеп чыккан иске кәнәфигә барып утыра.* Ә.Камал

**Түнтәеп китү** Кисәк түнтәю

**ТҮНҮ** *ф. сөйл.* 1) Берәр якка аву, егылу. *Манара кайсы якка түним икән дигән сыман аз гына чайкалды да тракторга ияреп янтайды һәм, мәктәп түбәсенең бер өлешен шатыр-шотыр җимереп, гөрселдәп җиргә ауды.* Г.Тавлин. *Сугышчылар, яшеренергә урын таба алмыйча, ничек туры килде шулай җиргә түнделәр.* Ә.Галиев

2) *иск.* Кире кайту, кире әйләнеп кайту; дүнү. *Яу түнгәндә, батыр булыр; дау түнгәндә, акыл булыр.* Мәкаль

3) *иск.* Күчү, китү; дүнү. *Әткәй кичә ошбу фани дөньядан түнде.* Шура

4) Яту. *Әбүсөгыт бай төшермеш иде, салган-салган – лаякыл исергәнче эчсен иде, ичмасам, йокыга түнәр иде.* М.Хуҗин. *Тәүгиз дә дөм караңгыда ботинкасын салды, пинжәген урындык башына элде һәм шул килеш ятакка барып түнде.* Х.Камалов. *Без кайсыбыз кая түнгән идек – сикерешеп тордык.* Д.Галимов

5) *күч.* Ою, йоклап китү. *Бераздан Заһри шунда утырган җиреннән түнде; Шәяхмәт ашын ашап, бик рәхмәт, дип кайтып китте.* М.Мәһдиев. *Зөфәр белән Иван утырган урыннарында түнделәр.* Ә.Галиев

6) Зур кичерешләрдән, авырлыклардан һ.б.ш.лардан соң айнык фикер йөртә алмаслык хәлгә килү, миңгерәүләнү. *Кыйбламны җуеп әйтмим, җанымны ваклавым да түгел, һуштан түнәрлек хәсрәтемнән гаҗиз булып сөйлим...* Б.Камалов. *Я Алла, кичерегез, зинһар, кичерегез. Кайгы-хәсрәттән мием түнгән.* Г.Ахунов

7) *күч.* Фикер йөртүдә берәр якка өстенлек бирү, фикерне бору. *– Һаман да начарга түнеп уйлыйсың бит, кем, Назыйм! – дип картны ачуланды Мөһибә.* М.Хуҗин

8) *күч.* Бер төрдән икенче төргә әверелү, бер хәлдән икенче хәлгә күчү. *Явыз каениш хурлыгыннан, әнекәй, Түнәм инде тактага.* Җыр. *Төнге золмәт мәгъбәдендә ут сүнәр, Кайгыхәсрәтләр тәмам юкка түнәр.* С.Сүнчәләй. *Ул ах диюгә, күл төбенең кызыл гөлләре сарыга түнә.* Н.Исәнбәт

9) *күч. диал.* Иялләнү, гадәтләнү, өйрәнү, күнегү. *Ашамаска түнгән кеше*

10) *күч.* Кылану, кыланчыклану. *Түнмә инде, юләрләнмә!*

**Түнә башлау** Берәм-берәм әкренләп түнү; түнәргә тору

**Түнеп бетү** Бөтенләй түнү; барысы да түнү. *Килеп керде дә, үзен бик акыллы күрсәтергә теләп, күптән мәгълүм нәрсәләрне сибеп утырды егет. Тыңлыйтыңлый түнеп беттем.* Ш.Галиев

**Түнеп китү** Кисәк түнү. *Пиджакны урынына элим дигәндә, урындык тагын түнеп китте.* А.Гыйләҗев

**Түнеп тору** Күпмедер вакыт аралыгына түнү. *Кинәт Зәлиянең түнеп торган башы ачылып киткәндәй булды...* И.Иксанова

**ТҮҢ** *и. диал.* Куак; куаклык. *[Еракта] ла җирдән, әй, күренә Ак чәчәкләр аткан түң муел.* Бәет

**ТҮҢГӘЛӘК** *и. к.* **дүңгәләк**. *Аксак сарыкның авызына җил түнтәргән түңгәләк төшәр.* Әйтем. *Алар ерактан багана башына эленгән түңгәләккә ук аттылар, иске саламнан ясалган балбал карачкысына сөңге ыргыттылар.* Н.Фәттах

**ТҮҢЕЛҮ** *ф. иск.* Йөз чөерү. *Төсе изгедән түңелмә, төсе бозыктан түңел.* Мәкаль

**ТҮҢКӘЙТҮ** *ф. диал. к.* **түнтәрү** (*2 мәгъ.*). *Ачы бал исе килә! Берәр җамаякны түңкәйтеп җибәрергә диген син!* А.Гыйләҗев

**ТҮҢКӘРҮ** *ф.* 1) Егу, аудару, әйләндереп каплау

2) Кемне дә булса җиңү

**Түңкәреп җибәрү** Кисәк түңкәрү

**ТҮҢКӘЮ** *ф. к.* **туңкаю**. *Яндагысы янтайган, Саздагысы чөңкәйгән, Агалары туры утырган, Түрдәгесе түңкәйгән.* Табышмак. *Эреле-ваклы өйләрнең кайсы, сөзәргә торган үгез сыман, урам якка авышкан, кайсы ян-якка түңкәйгән, кайсы, аскы ниргәләре череп басылганлыктан, тәрәзәләре белән яртылаш җиргә сеңгән.* З.Фәйзи

**ТҮП** *и.* **1.** 1) Көнбагыш, киндер, рапс һ.б.ш. майлы культураларның орлыкларыннан маен сыкканнан соң кала торган коры калдык. *Маен сыгып чыгарганнан соң калган көнбагыш түбе терлекләр өчен туклыклы азык булып санала.* Биология. *Өйдәге шартларда май алу өчен, сырганак җимешләренең согын сыгалар, түбен ваклыйлар, киптерәләр һәм көнбагыш маенда ике атна буе җылы урында төнәтәләр.* Урман аптекасы

2) Җиләк-җимешнең согын сыкканнан, как җәйгәннән соң калган кабыклар, чүп-чар. *Марля өстендә калган түпне яхшылап сыгалар.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Шул сыгынтыдан гыйбарәт. *Ссудага ярыйсы гына акча булды, чак кына түп азык та вәгъдә иттеләр.* Казан утлары

**ТҮП-** *кис. к.* **түм-**. *Авыл каршындагы тау артыннан түп-түгәрәк кызыл ай килеп чыкты.* И.Гази

**ТҮПӘ́Й ИТҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **түп итү**. *[Балагыз] түпәй итә күрмәсен, үпкәсенә салкын тия күрмәсен.* Н.Фәттах

2) *күч.* Ялгышу, уңышсызлыкка очрау. *Андый гына «түпәй итүләр» була инде ул үскәндә...* Җ.Дәрзаман

**ТҮПӘЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **тәпәләү**. *Галимҗан башын тотып алгач, әлеге бозның җен суккандай аны да ару гына түпәләвен аңлап алды ата кеше.* С.Поварисов

**ТҮПӘ́Ч ИТҮ** *к.* **түп итү**

**ТҮ́ПВАКЛАГЫЧ** *и. тех.* Каты түпне ваклый торган махсус машина. *Ул безгә тамыразык юу машиналары, түп ваклагычлар бүләк итте.* А.Расих. *Түпләрне түпваклагычларда ваклап, башка төр концентрат азыклар белән катнаштырып ашаталар.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

**ТҮПЕ** *и. диал. к.* **түп**

**ТҮ́П ИТҮ** *ф.* Балалар сөйләмендә: егылу, егылып төшү, аву. *Тот, җаным, тот, аумасын, түп итмәсен, тот баскычын.* Г.Тукай. *Ике куллап морҗага тотынырга онытма. Түп итәсең югыйсә.* К.Нәҗми

**ТҮР** *и.* **1.** 1) Өйнең, бүлмәнең ишеккә каршы ягы. *Ишек ачучы Кәримә белән кабат сәламләшүне кирәксенмичә, ул туп-туры түргә узды.* К.Тимбикова. *Мәдинә, кергәч тә, түргә узаргамы, узмаскамы дип, бераз икеләнеп торды,*

*аннары --- бер кырыйга барып утырды.* М.Хәсәнов

2) Өйнең иң эчке ягы; хөрмәтле урын (анда гадәттә кунакларны утырталар). *Син ишектән кайтып керә идең Түргә кояш килеп кергән кук.* Х.Туфан. *– Ну, абый җаным, – диде Тавис, – өйне салып бетерсәм, иң түрендә иң кадерле кунак син булачаксың. Иң түрендә, иң кадерлесе...* М.Мәһдиев

3) Өйнең пөхтәрәк итеп җыештырылган эчке зур бүлмәсе (аш һәм йокы бүлмәсенә каршы куела). *Туган өйнең ишеге дә ипле, Түрләре дә иркен күренә.* Ф.Гыйззәтуллина. *Малайны өйнең түрендәге йомшак урынга илтеп салдылар.* Р.Мөхәммәдиев

4) Басу, кыр, урман, бакча, ишегалды кебек берәр киң яки озын мәйданның кеше басып торган урыннан эчкәрәк, ерактагы, аргы ягы. *Кайсыдыр бер язны – утыз дүртенче елнымы икән – басу түрenә, җир селкетеп, трактор килеп туктады.* М.Мәһдиев. *Болын түрләрендә ал рәшә, Җәйге ялкын капкан болынга ---.* Х.Әюп

5) Берәр нәрсәнең иң эчке урыны, эче; уртасы. *Мин, шалаш түренә аякларымны сузып, башымны чыгарып, күккә карап яттым.* М.Мәһдиев. *Өстәл түрендә утырган самавыр байтактан кайнап чыккан иде инде, күтәрелгән парда лебер-лебер җиз түбәтәйләре сикергәләп тора.* Р.Мөхәммәдиев

6) Арба-чана кебекләрнең арка сөяп утыра торган урыны. *Кем белә, бәлки, Мөршидәсе иренең исән калуына сөенеп, аны арба түренә утыртып алып кайтыр иде.* М.Хуҗин. *Алсу да нәкъ шул чакны, чана түрендәге урыныннан кымшанып, аңар нидер дәште, кул болгады төсле.* Р.Мөхәммәдиев

7) Өйнең, бинаның алгы, фасад ягы. *Йорт түренә ялгыз каен Нигә утырттың, иркәм? Ялгыз каен кайгыга, дип, Нигә әйтмәдем икән?!* Р.Вәлиева. *Өй түремдә алма коела таңда, дөп-дөп коела чыклы үләнгә!* Р.Әхмәтҗан

8) *куч.* Иң яшерен, иң эчке, кеше белмәслек-сизмәслек урын (гадәттә *йөрәк, күңел* сүзләре белән килә). *Сез һаман саф, сез һаман да ямь-яшь, Сез һаман да күңел түрендә.* Ш.Галиев. *Ах, бу якты, күзге кояшлы көн Бигрәк моңсу булып күренә. Сентябрьнең сары яфраклары Коела күк хәтер түренә ---.* Л.Шагыйрьҗан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Түрдәге, ишеккә каршы яктагы, алдагы, иң эчке. *Түр яктагы бер бүлмәне Гөлләриягә биргән идек. Анда әле дә аның әйберләре тора.* К.Тимбикова. *Түр табында тик утырсын шаулап: Самавырың кайнат, иренмә!* Ф.Гыйззәтуллина. *Түр бүлмә ишеге ачылып, аннан әниләре күренде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Эчке, аргы, берәр мәйданның аргы башына урнашкан. *Түр бакча*

◊ **Түргә уз** *к.* **түрдән уз**. *– Уз түргә, әнә урындык, утыр. Баедың син, бер бинада эшләсәк тә, күзгә-башка сирәк күренәсең, – дип үпкәләп каршылады ул мине.* Г.Тавлин. *Түргә... чишенеп, түргә узыгыз. Хәзер чәй куеп җибәрербез. Чәйләп алырбыз... җылынырсыз да...* М.Хәсәнов. **Түрдән уз** Кунакларга илтифат итү, ихтирам күрсәтү йөзеннән, өйнең, бүлмәнең эчке ягына – хөрмәтле кунаклар урынына үтәргә тәкъдим итеп әйтелә. *Һай рәхмәт төшкерләре, мактап йөрисез икән, түрдән узыгыз, әллә ни сый-хөрмәт юк югын.* М.Шабай. *И-и, кунак бар икән! Әйдә кер, Хәдичә, кер, чишен, түрдән уз.* М.Хәсәнов

**ТҮРӘ** *и.* 1) Җитәкче, эш башында торган кеше, башлык; чиновник, мәэмүр. *Үзен зур тоткан түрәнең соңы хур була.* Мәкаль. *Ә безнең илдә җитмеш ел эчендә дәүләт башлыклары да, урыннардагы түрәләр дә ничәмә-ничә тапкыр (санап бетергесез!) йөзләрен югалттылар инде, әмма берсе дә үзен-үзе үтергәне булмады.* Г.Ахунов

2) Хуҗа, хаким. *Өендә хатынына түрә булмаган – илдә халыкка түрәлек иткән.* Мәкаль. *Ай, түрәм, ай! Безне кемгә калдырдың, ай!* Г.Ибраһимов

3) *хурл.* Үзен кешеләрдән өстен исәпләүче, башкаларга кимсетеп караучы кеше, һавалы, тәкәббер кеше. *Шушы зур булмаган әсәрдә язучы чорның бөтен катлаулылыгын, каршылыгын, гади кешеләрнең күңел байлыгын, түрә кыяфәтле бәндәләрнең җансызлыгын аңнарга үтеп керерлек итеп тасвирлый алган.* Ф.Сафин

4) *бор.* Гореф-гадәт, йола, тормыш кагыйдәләре, закон. *Ятып калганчы атып кал! Ерак бабалары шушы сүзне юкка гына түрә итеп алмаганнардыр.* Р.Зәйдулла

5) *бор.* Суд, хөкем. *Тилегә түрә юк.* Мәкаль. *Түрәгә түрә булырлык Бер тылсым тапсаң инде! – Ул чакта аның эте дә Сәламнәр бирер иде.* Ә.Рәшит

6) *бор.* Судья. *Бакыр бабам дәүләт судьясы, түрә хезмәтендә торган, Ә зат бабам исә Кызыл армиядә Фрунзе дивизиясендә сугышып, яраланып кайтып, гаиләсен барча байлыкларыннан котылдырып һәм азат итеп, савыга алмыйча вафат киткән.* Ф.Яхин

7) *бор.* Акыл бирү, киңәш итү, фикер әйтү, катлаулы мәсьәләне чишү. *Үндүртенә килгәндә Үндүрт дауны бетереп, түрәсен биргән ул [Идегәй] булды.* Дастан

◊ **Түрәнеке түрдән** Хакимият башында булган кешеләр һәрвакыт үз урыныннан файдалана, аның үз мәнфәгатьләрен кайгырту өчен, мөмкинлекләре күбрәк булу турында. *– Түрәнеке түрдән, дип әйткән бит халык. Нишлисең, туганнар, дөньяның тәртибе шундый булгач, без генә үзгәртә алмабыз инде, – дип дәвам итте Сөләйман абзый.* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮРӘ́-КАРА** *җый. и.* Хакимият башында торучы кешеләр, һәртөрле власть вәкилләре, чиновниклар, хакимнәр, түрәләр. *Ул, әлбәттә, үзен күрсәтеп, түрә-караны ихтирам иткәнлеген белдереп, эшләренең ничегрәк тәгәрәвен өстән-өстән генә сөйләп --- кайтып та китә алган булыр иде.* Г.Ахунов. *Сез түләнмәгән салымнарыгызны икеләтә арттырып түләргә, бездән качкан түрә-караларның барысын да безгә кире кайтарырга тиеш.* Р.Зәйдулла

**ТҮРӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Үзен түрәләрчә тота башлау, түрәләр гадәте алу, түрәләрчә (*1 мәгъ.*) кылана башлау

2) Масаю, эреләнү, тәкәбберләнү

**Түрәләнеп йөрү** Бөтен җирдә, һәркем алдында эре кылану, масаю

**ТҮРӘЛӘ́РЧӘ** *рәв.* **1.** Эре кыяфәт белән, тәкәбберләнеп, эреләнеп, үзен өстен куеп, кешене кимсетеп, өстән

аска карап. *Ул инде, әлбәттә, гади генә сөйләшми: җитди, түрәләрчә, үзе көлми дә; тавышын тәмам начальникларча чыгарырга тырыша.* Г.Ибраһимов. *Монысында ул мине түрәләрчә түгел, кабинетының ишеге төбендә, бүлмәсенә кергәч тә, кул биреп, якты йөз белән каршылады.* Г.Тавлин

**2.** *с. мәгъ.* Түрәләргә хас булган, тәкәббер, артык эре, масаюлы. *Түрәләрчә кыланыш аңа каян килгән, нигә аның сүзләре, кем әйткәндәй, бөереннән генә чыга?* Г.Тавлин

**ТҮРӘЛЕК** *и.* 1) Түрә (*1 мәгъ.*) дәрәҗәсе, җитәкче булу хәле. *Әти, син мине башкалар шикелле эшли алмас дип уйлыйсыңмы, әллә андый эшкә керешүем түрәлек абруеңа сугамы?* Н.Әхмәдиев. *Түрәлек ул – килә-китә торган, Ә шагыйрьлек кала. Беләсең.* Р.Миңнуллин

2) *күч.* Эреләнү, масаю, үзен башкалардан өстен кую гадәте, эрелек, тәкәбберлек. *Ләкин гомумән түрәлектән түгел, ә түрәлекнең аерым бер, аеруча ләззәтле бер мизгелендә яшәреп, сафланып китәләр алар.* М.Мәһдиев. *Әдәби түрәлек аның [Роберт Әхмәтҗановның] иң куркыныч дошманнарының берсе булды.* А.Хәлим

**ТҮРӘСЕЗ** *с.* **1.** Җитәкчесез, башлыксыз; идарәсез, идарә ителми торган

**2.** *рәв. мәгъ.* Җитәкчесе, башлыгы булмаган килеш; идарә ителмичә. *Түрәсез калган киң йортың Түрәсен көткән мин икән – Үзем Чыңгыз түгелме?* Дастан. *Ил түрәсез яшәмәгән кебек, базар да кәмитсез булмый, әмир.* М.Хәбибуллин

**ТҮРӘ́Ү** *ф. диал.* Бала табу, бала тудыру. *Әни ике кыз, ике малай түрәгән*

**ТҮ́Р БАКЧА** *и.* Өйнең алгы, фасад ягындагы кечкенә бакча; урам бакча; *русчасы:* **полисадник**. *Түр бакчама гөлләр чәчтем Алларын сайлап кына. Алар сары чәчәк атты – Хәйраннар калдым шуңа.* Р.Вәлиева. *Мәңге булмас түр бакчамда Кызарыплар чия пешкән. Ефәк пәрдәләрем аша Кичке кояш нуры төшкән...* Л.Шагыйрьҗан

**ТҮРБАШ** *и. к.* **түр башы**. --- *клубның түрбаш почмагындагы ташлар бик җиңел алына* ---. М.Галиев

**ТҮ́Р БАШЫ** *и.* Өйнең, бүлмәнең, табынның иң хөрмәтле, иң уңайлы урыны. *Фёкла түти түр башында, зәңгәр рам эчендә торган шамаилгә ымлый.* А.Хәсәнов. *Ташлашкан егетем дип тормаган, тартынмаган, хурлана белмәгән: кергән. Алай гынамы әле, түр башына үк менеп, кукраеп утырган.* С.Зыя

**ТҮРГЕ** *с.* Түр яктагы, түрдәге, ишеккә каршы яктагы. *Фатыйма белән Таибә тиз генә өстәлне түрге чаршау артына алып югалалар.* М.Фәйзи. *Түрге почмакта кунакларның аслыөсле куелган багаж-сумкалары [ята].* Ә.Фәйзи

**ТҮРЕМ** *с. диал.* Калын, юан. *Мамык эрләткән идем кешедән, тигез эрләмәгән, түрем урыннары бар*

**ТҮРЛӘМӘ** *и. этн.* Түрдә түшәм белән тәрәзә башы арасындагы икеөч ниргәне каплау өчен эленә торган озынча, тар бизәкле чаршау, пәрдә. *[Өйдә] һәр татар өендә очрый торган кашага, түрләмә, почмакларга эленгән сөлгеләр [күренә].* С.Рафиков. *Миллион төсләргә буялган түрләмәләр, авыр ефәк шәлнең тылсымлы чуклары әкрен генә тирбәлә башладылар...* Г.Сабитов

**ТҮРЛЕ** *с.* Түре (*6 мәгъ.*) булган, җайлап терәлеп утырырлык урынлы итеп эшләнгән. *Түрле чанага яхшы ат җиккән бер юлчы урамда карлар уйнатып, чаптырып узып китә.* Ф.Хөсни. *Түрле чанада икәү баралар. Райүзәккә таба киләләр. Юл буш. Туры айгыр күңелле генә юырта.* М.Хәсәнов

**ТҮРЛЕ́-ПОЧМАКЛЫ** *рәв. к.* **ишекле-түрле**. *Федюшкин, яраланган аягы белән аксый-аксый, читлектәге аю кебек, түрле-почмаклы йөренә.* И.Гази

**ТҮ́Р ЮРГАНЫ** *и. этн.* Традицион татар өендә кунакларны утырту өчен, идәнгә яки сәкегә җәелә торган палас яки тар көрпә. *Аның да түрендә буйданбуйга тар гына итеп сырылган корама юрган сузылган. Анысын түр юрганы дип йөртәбез.* М.Әмир

**ТҮ́Р ЯК** *и. к.* **түр** (*3 мәгъ.*). *[Агай] өйне искечә салдыра: түр як та почмак як, түшәме тәбәнәк.* Г.Бәширов. *Төнге дала җиленә чатыр ефәге лепердәп куя, түр якта утка май салучы кол йокымсырап утыра.* М.Хәбибуллин

**ТҮТӘ** I *и.* 1) Балта тимеренең сырт ягы; йөзенә каршы ягы. *Наймуш имән борысны җиренә җиткереп ышкылады, --- пычкы һәм өтерге белән тигез, пөхтә итеп ырмаулады, балта түтәсе белән борысларны бер-берсенә кагып кертте.* Ә.Гаффар. *Сарайда ята колун балта. Түтәсе иңгән күп сугудан, Йөзе тонган тутыгудан.* Р.Фәйзуллин

2) Чүкеч тимеренең юан, тумпак башы

3) Мылтык, автомат һ.б.ш. утлы коралның, атканда, иңбашка тери торган киң тоткычы, төп ягы; *русчасы:* **приклад**. *Тимерче осталарда, һөнәрчеләрдә – шам кылыч, хәнҗәр, көбә, ук-җәя, сөңге очы, түтәләре көмешләп бизәлгән мылтык, тимер баш киемнәре...* Ф.Латыйфи. *Озын торыклы немец солдаты аны бик тиз куып тотты һәм автомат түтәсе белән аркасына орды.* Р.Сибат

**ТҮТӘ** II *и. диал.* Үзеңнән олырак хатын-кыз, апа, тута. --- *безне дә чыгарып җибәрерләр.* --- *Теге абыеңнар. Түтәңнәрне дә чыгарып җибәрделәр әнә...* Х.Сарьян. *Баһау абыйсы белән түтәсенең ул чактагы яхшылыкларын Тимерханның гомердә дә онытасы юк.* Г.Ахунов

**ТҮТӘ** III *с. диал.* Кыска һәм туры. *Арка (биек) җирләрдән болан үтә, Зөлхиҗҗә... Арка җирдә юллар түтә дип.* Җыр. *Карт төртә, таяк болгап: «Әйдәгез, – ди, – түтә юлга».* Яшь ленинчы

**ТҮТӘЙ** *и. к.* **түти**. *Мәрьям шул йортта яшәүче ялгыз карчык Дуся түтәйдә квартирада яши иде.* М.Маликова. --- *шул ук Гөлбикә, Хөппениса, Миңниса түтәйләр пешерүен дә пешерә, миски-тәлинкәләргә салып та бирә иде.* Ф.Баттал

**ТҮТӘЛ** *и.* 1) Яшелчә яки гөлләр утырту өчен, тар озынча яки түгәрәк формада казып йомшартылган туфрак мәйданчыгы. *Чәчәк түтәлләре янындагы урындыкларга кырын ятып, үткәннәрне искә төшерәләр, кайдан килүең, кем булуың белән кызыксыналар, таныш-белешләрен сорашалар.* Ш.Рәкыйпов. *Түтәлләргә кырпак төшкән*

*мәлдә, Чын чәчәкләр җирдә калганмы?* Ф.Гыйззәтуллина

2) Шундый бер урында үскән яшелчә микъдары. *Дөрес, аның бакчасы да бакча түгел: бер-ике түтәл кишер, суган утыртырлык уч төбедәй җире бар.* Н.Фәттах

**ТҮТӘ́Л-ТҮТӘЛ** *рәв.* Түтәлләр рәвешендә, түтәлләр ясап; түтәлләр тутырып, берничә түтәл рәттән. *Оҗмахтай ул бакча, түтәл-түтәл чәчәк белән балыклы күлләр миңа гына кирәкмени?* В.Имамов

**ТҮТӘНӘ** *с. диал.* **1.** Аш-су аермаучы, аш-суның рәтен белмәүче, талымсыз

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Түтәнәгә алма – шалкан, ком – талкан, чыпчык тизәге – канәфер.* Мәкаль. *Түтәнәгә түп тә талкан.* Мәкаль

**ТҮТӘПКЕЛ** *с. диал.* Һәр яктан уртача: яшь тә түгел, карт та түгел; симез дә түгел, ябык та түгел. *Көтүгә әле генә чыгарылса да, сарык ябык түгел, түтәпкел генә.* Шура

**ТҮТӘПЛЕ** *с. диал.* Көр, таза. *[Ул] картаебрак өйләнгән булса да, үзенә караганда яшьрәк булган, бик түтәпле Газзә абыстайны эләктергән.* Г.Кариев турында истәлекләр

**ТҮТӘРӘМ** *и.* 1) Дүрттән бер өлеш, чирек. *Нәҗипнең җылыйсы килеп китте, күңеле тулды: «Бер түтәрәм каклаган казлары, бер йомарлам ак майлары да юк микәнни боларның?» – дип өзгәләнде.* А.Гыйләҗев

2) Дисәтинәнең алтыдан бер өлешен тәшкил иткән борынгы җир үлчәү берәмлеге. *Быел ашлык бик күп чәчтем: бер түтәрәм тарым бар.* Җыр. *Киң даланың һәрбер түтәрәме сусау белән сусый.* Ә.Фәйзи

3) Бер кадак, авырлык үлчәүнең якынча 400 граммга тигез берәмлеге

4) Зур кисәк (ит, икмәк һ.б.ш. тур.); гомумән, кисәк, өлеш. – *Тукта, менә монда әз генә бар икән, – дип, Сабиратти киң пычак белән мул гына кисеп, бер түтәрәм майны баланың савытына сала.* М.Мәһдиев

**ТҮТӘРӘМЛӘП** *рәв.* 1) Түтәрәме (*2 мәгъ.*) белән, түтәрәм артыннан түтәрәм итеп. *Эш харап монда: түтәрәмләп җыйналган җирләремнең яртысыннан артыгы ычкынганын да сизмәдем.* Ф.Бурнаш

2) Зур-зур кисәкләп

**ТҮТӘРӘМ-ТҮТӘРӘМ** *рәв.* Түтәрәмләп; гомумән күп иттереп, зур-зур кисәкләр белән. *Авыл җирендә каздан да җайлысын тапмый иек. Көздән тозлап әләсең дә, җәй буе түтәрәм-түтәрәм ит ашыйсың.* А.Гыйләҗев

**ТҮТЕК** *и. сир.* Сыбызгы. *Малайлар авызындагы таш түтекләр тал сандугачы тавышлары чыгарып сайрыйлар.* И.Гази

**ТҮТЕКӘЙ** *и. ирк. к.* **түти**. --- *агасының этләре баягыча тагын өрә башлыйлар: – Баерга киткән түтекәй үлеп кайта түгелме, ләң-ләң! – диләр.* Әкият. – *И-их, әйттерә дә соң безнең Мәрьям түтекәй! – дип, кемдер җыр арасында аны мактап алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮТЕЛДӘТҮ** *ф. диал.* 1) Баланы үбәүбә яки артын чәбәкли-чәбәкли сөю

2) *күч. хурл.* Бик иркәләү; үсендерү, үчтекиләндерү. *Аны безнең мәрхүм профессор артык түтелдәтте шул*

**ТҮТЕЛДӘ́Ү** *ф. диал.* Кылану, кыланып сөйләшү

**ТҮТЕШ** *и. диал. к.* **түти**. *Чакыр, түтеш, чакыр!* Э.Касыймов. *Әгәренки миңа гына ышанмасаң, Зәмзәмбану түтештән сора.* Г.Әпсәләмов

**ТҮТИ** *и.* Үзеңнән олырак кыз туганны һәм гомумән яше белән зуррак хатын-кызны атау яки аларга эндәшү сүзе; апа. *Аштан соң Зада апага мин әти белән әни һәм үзем турында аңа кадәр Хәбибә түтигә һәм Мирсәет абыйларга сөйләгәннәремне җәелмичә генә кабатладым.* Г.Тавлин

**ТҮТ-ТҮТ** *иярт.* **1.** Автомобиль һ.б.ш.ларның сигнал биргәндә чыгарган тавышын белдерә. *[Әткәй] машинаны әлегә үзе йөртә: Түт-түт-түт-түт!* Ш.Галиев

**2.** *ы. мәгъ.* 1) Берәр нәрсә яки эш бетү, югалу турында

2) Китеп бару яки качып китү турында. *Исең киткән икән. Ул барыбер иртәгә иртә белән үк түт-түт!* К.Нәҗми

**ТҮ-ТҮ** *иярт.* **1.** Тынлы музыка коралында уйнаганда, сигнал биргәндә чыккан өзек-өзек нечкә тавышны белдерә. *[Зыя]: «Ту-ту-ту, траттытам, траттытам», – дип, аякларын танец көенә хәрәкәтләндереп, рояль янына барды.* Ф.Әмирхан

**2.** *ы. мәгъ.* Берәр эш яки нәрсәнең күптән бетүе яки юклыгы турында. *Кылана да соң инде, Һай бу яшьләр-шәрләр. Безгә ту-ту шул хәзер Тегебу ишарәләр...* Ш.Галиев. *Ту-ту бит әти апаң! Толымнары белән кулларын урап озаттык без аны!* М.Маликова

**ТҮ-ТҮ́ ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Мич артында ту-ту итеп телеграф аппараты эшли.* Г.Галиев

**ТҮ-ТҮТ** *ы.* 1) Берәр нәрсә китү, югалу турында

2) Берәр нәрсә яки мөмкинлек бетү турында

**ТҮ-ҮТ** *ы. к.* **түт-түт**. *Үсә төшеп, башкаларның әтиләре барлыгын белгәч, минем әти кая, дип сорый башласа, әнисе: – Әтиең ту-үт китте! – дип җавап бирә иде.* М.Маликова

**ТҮЧӘ** *ы.* Бозау яки сыер куганда әйтелә

**ТҮШ** I *и.* 1) Гәүдәнең (бигрәк тә хайван гәүдәсенең) муен белән корсак арасындагы чыгыбрак торган өлеше; күкрәк. *Тук казларның, утырган җиреннән генә түшен биетеп, борын эченнән генә гаң-гаң килеп гәпләшүләре...* М.Гали. *Менә машинадан уртача буйлы, хәрби киемле, түшендә «Алтын йолдыз» медале һәм ике Ленин ордены балкыган кеше төште.* Г.Тавлин

2) Берәр нәрсәнең алгы өлеше, уртасында алга чыгыбрак торган җире. *Чиркәү үр кашында ук түгел, түбәндәрәк, үрнең түшендәрәк.* Ә.Гаффар. *Борынгы грек галерасы (җилкәнле судно) үзенең текә түше белән Урта диңгез суларын кисеп йөри икән.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

3) Хатын-кыз күкрәге. *Иң алдагы машинада, колхоз «Волга»сында, изүләрен чишеп җибәреп, түшләрен киереп, Саттар Хәбирәсе утыра иде.* М.Хәсәнов. *Хатын шактый мулдан киерелгән түшләрен әле берсенә, әле икенчесенә таба борды.* Н.Хәсәнов

◊ **Түш белән каплау** *сир. к.* **күкрәк белән каплау**. *Явызлыкның юлын каплыйм түшем белән.* Г.Афзал. **Түш**

**киерү** Горур кыяфәт чыгару, эреләнү, һавалану. *Милләт өчен эш кырмаса да тиенлек, Масаеп түш киереп алар йөрерлек.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Карале, малай, карале, ул түшләрен киереп торуларын гына күр син аның...* Р.Мөхәммәдиев

**ТҮШ** II *и. к.* **түшкә**. *Анда сыер, сарык, дуңгыз түшләрен эскерт-эскерт өеп куялар. Ягъни ит түшләрен, салкында катырыр өчен, штабельләргә салалар.* Н.Дәүли

**ТҮШӘК** *и.* 1) Эченә тавык йоны яки каз мамыгы тутырып ясалган, аска салып ята торган озынча зур ястык. *Кунакка түр яктагы караватка, ничә еллар җыеп килгән каз мамыгыннан ясалган йомшак түшәкләрен кабартып, урын җәйде.* Р.Мөхәммәдиев. *Чишендем. Йомшак түшәккә чумып яттым. Өстемә йомшак йон юрган ябындым. Тәнем рәхәтлеккә чумды.* М.Юныс

2) *диал. к.* **көрпә** I (*3 мәгъ.*). *Алар байтак вакыт шулай, үзләренең салам түшәкләрендә сузылган килеш, [сөйләшеп яттылар].* Ш.Камал. *Мамыклы орлыкларны мендәр һәм түшәкләргә тутыру өчен дә файдаланырга ярый.* Робинзон эзләреннән

3) Гомумән урын-җир. *Көне җитеп егылган берәү Түшәгендә җан биреп ята.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Сания, баланы түр түшәккә кертеп салгач та, озак кына тынычлана алмады.* Г.Гыйльманов

◊ **Түшәгеңә карап аягыңны сузу** *к.* **юрганыңа карап аяк сузу**. *Кода-кодагыйлар, түшәгеңә карап аягыңны сузарсың дигәндәй, елларның байлыгына чамалап, туй да ясап алдылар.* М.Шәрифуллин. **Түшәгеңә күрә аягыңны сузу** *к.* **түшәгеңә карап аягыңны сузу**. *Шулкадәр акча тыгып дача салу нигә хаҗәт иде соң? Ник болар түшәкләренә күрә генә аякларын сузмыйлар икән соң?* Ш.Мөхәммәдев. **Түшәк өстенә егылу** Йөри алмаслык булып, бик нык авырып китү. **Түшәк өстендә яту** Бик нык авыру, урыннан тормаслык дәрәҗәдә авыру; урын өстендә яту. *Мәрхүмә ничә көннәр түшәк өстендә ятты, куркулыклар койдырды.* М.Мәһдиев. **Түшәк саклау** Берүзе генә йоклау (гадәттә ирсез хатыннар тур.). *Хатыны Зәйтүнә --- үзе югында нишләп йөрим мин анда дип, кечкенә кызлары Мәрьямне кочып, тагын түшәк сакларга яткандыр.* Э.Касыймов. **Түшәк яңарту** Икенче хатынга өйләнү. **Түшәккә аву** *к.* **түшәк өстенә егылу**. *Тәмам хәлсезләнеп түшәккә ауган кыз сөйгәне Рамай турында җырлар чыгара, аларны көйгә салып җырлый.* Җ.Фәйзи. **Түшәккә егу** Каты авыруга сәбәпче булу. *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар --- аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов. **Түшәккә егылу** *к.* **түшәк өстенә егылу**. *Аяк өсте гамәлдә йөгереп йөргән әнкәбез көтмәгәндә түшәккә егылды.* Ф.Яхин. *Хан янә Ширванны хәтерләп куйды, атасының авырып түшәккә егылуын ишеткәч, ул үзенә тәгаенләнгән биләмәсен ташлап, Сарайга кайткан иде.* Р.Зәйдулла. **Түшәккә менү** *к.* **түшәк өстенә егылу**. **Түшәктә яту** *к.* **түшәк өстендә яту**. *Димәк, Закирның хаста түшәгенә ятуында гадәттән тыш бернәрсә юк.* Ш.Рәкыйпов. *Җиде-сигез ел түшәктә ятып, бик күп газаплар кичергән иде инде мескен Камәр.* М.Хәсәнов

**ТҮШӘ́К ҖӘЙМӘСЕ** *и.* Ятканда, түшәк өстенә җәя торган җәймә; простыня

**ТҮШӘКЛӘНҮ** *ф.* Түшәк рәвешенә килү, түшәк рәвешен алу. *Күперенә, түшәкләнә [болыт], ата Ходайның тупларын.* М.Укмасый

**ТҮШӘ́К-МЕНДӘР** *җый. и. к.* **түшәк-ястык**. *Сара карчык Хабулның түшәк-мендәрен рәтләде, йомшак чүпрәкне җылымса суга манчып, иренең битен сыпырып чыкты ---.* С.Лашманчы

**ТҮШӘ́К-ТҮШӘК** *рәв.* Калын булып. *Боз өстенә түшәк-түшәк кар яуды.* Г.Ахунов

**ТҮШӘК-ЯСТЫК** *җый. и.* Һәртөрле урын-җир әйберләре, түшәкләр һәм ястыклар. *[Хатын] киң агач ятакның өстенә тау-тау өелгән түшәк-ястыкларны, мендәрләрне яңадан кайтарып җәйде.* Г.Ибраһимов. *Сандык өсләренә яңа тышланган түшәк-ястыклар өелгән.* Г.Галиев

**ТҮШӘЛМӘ** *с.* **1.** 1) Җиргә җәелеп, якынаеп үсә торган. *[Дарулык яушан] 10–30 см озынлыктагы, күп тапкырлар тамырланучан, күтәрелмә очлы, түшәлмә сабаклы күпьеллык үлән үсемлек.* Урман аптекасы. *Ак чыршының аскы ботаклары җиргә кадәр тиеп тора һәм бик озак түшәлмә үсемлек кебек үсәргә мөмкин.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Сазлык, баткак яки комлы җир өстенә бүрәнәләр, такта яки чыбык-чабык җәелеп салынган. *Бераздан аларның атлары сазлык аркылы салынган түшәлмә юлны дөбердәтеп баралар иде инде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **түшәмә** (*1 мәгъ.*). *Юкәнең җиргә коелган яфраклары, иманнекеннән аермалы буларак, тиз чери. Менә ни өчен юкә урманында туфрак түшәлмәсе булмый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *бот.* Яфракның үткәргеч бәйләмнәр тирәсендәге күзәнәкләр катламы; *русчасы:* **обкладка**

**ТҮШӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **түшәү**. *--- подвал эшкә ярарлык түгел инде. Искерде. Стеналары яссы ташлардан өелгән, түшәмәнә урталай ярылган имән бүрәнәләр түшәлгән.* Ә.Гаффар. *Аның [ниндидер корылма] урынында җәлпәк ташлардан түшәлгән сөзәк калкулык кына калган.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Берәр төрле йомшак, күпереп торган нәрсә белән каплану. *Нинди ямьле безнең үзәннәр, Түшәлгәннәр йомшак хәтфәләр; Ал чәчәкләр, яшел үләннәр Яшьлегемне хәтерләтәләр.* Ә.Ерикәй. *Сабантуй Вәрәшбашта Тимерханның ындыр артында каз бәпкәсе үләне түшәлгән тугайда уза торган иде.* Г.Ахунов

3) Берәр җирдә рәттән күп кеше яту, аунап йоклау

4) *күч.* Күпләп үлеп яту. *Күпер аркылы качып барганда, утызлап фриц түшәлеп калган.* И.Гази. *Мин үткән йөзләрчә чакрым юл гел безнең солдат гәүдәсе белән түшәлгән иде.* Ф.Сафин

**Түшәлә бару** Рәттән түшәлү

**Түшәлә башлау** Түшәлергә тотыну. *Кояш әле баемаган, ләкин яр астында эңгер түшәлә башлаган инде.* М.Хә-

бибуллин. *Кап-кара җир өстенә түшәлә башлаган ак кар бөртекләре күзгә төшенкелектән бер ярдәм кебек.* Д.Булатова

**Түшәлеп бетү** Барчасы да түшәлү

**ТҮШӘМ** *и.* 1) Бинаны, өйне, бүлмәне өске яктан каплап, такталардан яки плитәдән эшләнгән эчке капламасы. *Яшь галимнәр түшәмне кубарып ташларлык тавыш чыгарып көлгәннәр иде ул чакта.* К.Тимбикова. – *Шундый бер яктырткычны түшәмеңә асып куйсаң, ә! – дип уйлады ул.* З.Фәтхетдинов

2) Берәр корылманың эчендәге куышның өске өлеше, көймәсе, аңкавы, гөмбәзе. *Бу гарәп шуны [камырны] озын тимер көрәгенә кабул итә дә мичнең түшәменә тезә.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Берәр эштә, сыйфатта ирешү мөмкин булган иң югары күрсәткеч; мөмкинлекләр чиге. *Аның [Госманның] түшәмен без шунда ук күрдек. Моннан соң ул, ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак.* Ф.Хөсни. *Кулына бәйләү өчен йомшак, зәгыйфь әсәр килеп керсә дә, Гариф абый [Ахунов], каләм иясенең түшәмен, сәләт дәрәҗәсен чамалап, күтәрелеп бәрелмәс, авторның күңелен җәрәхәтләмәс.* Т.Галиуллин

4) *күч.* Рөхсәт ителгән күләм, мөмкин булган соңгы чик

5) *күч.* Самолёт, снаряд һ.б.ш. күтәрелә ала торган биеклек чиге. *Очкан саен совет пилотының очу түшәме гел югарырак күтәрелә барды.* Казан утлары

◊ **Түшәм санаш** Шаяртуның асылын белмәгән кешене чалкан яткырып, кием җиңеннән түшәм такталарын санатып, җиңгә су коюдан гыйбарәт уен. **Түшәм санап яту** *к.* **түшәмгә төкереп яту**. *Арган чагы була, борчулы чаклары, мәгәр аның йокысыз интегеп, түшәм санап, көндәлек уңышларына яки хаталарына анализ ясап ятканы юк.* А.Гыйләҗев. **Түшәмгә төкереп яту** Эшләмичә, вакытны әрәмгә уздыру, ялкаулану. *Шул «ләкин» дигән каһәр суккан сүз булмаса, без әллә кайчан коммунизмга барып җитеп, түшәмгә төкереп ята идек инде.* А.Гыйләҗев. *Бу минем соңгы китүем булачак. Шуннан кайткач, менә ипекәй, ындыр артына да чыкмыйча, авылда түшәмгә төкереп ятачакмын.* М.Юныс. **Түшәмнән алу (бирү)** Куелган таләпкә, бирелгән сорауга туры килмәгән, уйланылмаган, кирәк булмаган, нигезләнмәгән теләсә нинди соралган мәгълүмат бирү. *Түшәмнән чүпләп булса сан, тупла план, Уң кесәдән ал да сип башлыкка мактау.* Ә.Баян. *Булырга, монда эш югарыда утыручы түрәләрнең түшәмнән алып җибәргән планнары буенча бармый бит, ирекле кешеләр хезмәте бу!* З.Фәйзи. **Түшәмнән таракан санап яту** *к.* **түшәмгә төкереп яту**. *«Казремстрой» тресты да түшәмнән таракан санап ятмый, ул да баш вата, ул да эзләнә.* Социалистик Татарстан. **Түшәмнән туфрак коюы** Бик каты ачуланып котырыну, тавышлану, дулау. *Наиләнең, сирәк-сирәк кенә булса да шулай дулап, түшәмнән туфрак коя торган гадәте бар.* Ф.Хөсни

**ТҮШӘМӘ** *и.* **1.** 1) Берәр урынга тоташ түшәлгән такталар яки бүрәнәләр рәте

2) Гомумән, берәр өслекне тоташ каплаган катлам. --- *[имәннең] каты яфраклары туфракка түшәмә булып ята, аның яфраклары бик озак чери, черегәндә, туфракка дуплау матдәләре бүлеп чыгара.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

3) *диал.* Лапас, лапас башы

**2.** *с. мәгъ. к.* **түшәлмә** (*2 мәгъ.*). *Шоссе юл бетүгә, түшәмә юл башланды. Саз җиргә күп итеп ылыс, агач ботаклары җәелгән.* Ә.Маликов

**ТҮШӘМЛЕ** *с.* Түшәме ясалып беткән, түшәме булган, түшәменең берәр үзенчәлеге булган. *Әмировның сарае зур түгел, тәбәнәк кенә түшәмле.* Х.Вәлиәхмәтов

**ТҮШӘМЛЕК** *с.* **1.** Түшәм ясарга яраклы, түшәм түшәргә җитәрлек, шуның өчен махсус әзерләнгән. *Матчалыклар, идән сайгаклары, түшәмлек, идәнлек такталар әзер.* Б.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* Түшәм өчен такта яки плитә. *Янәшә генә түшәмлекләр сайлап куелган.* Г.Галиев

**ТҮШӘНҮ** *ф.* Ятып йокларга урын җәю. *Ястанганың яфрак, Түшәнгәнең туфрак.* Әйтем. *Солдатның ятыр ястыгы юк, түшәнер түшәге юк.* Мәкаль

**ТҮШӘ́Ү** I *ф.* 1) Ятып йоклар өчен ятак әзерләү, урын-җир әйберләрен җәю. *Түргә, төрле чүпрәк кисәкләреннән корып, түр юрганы түшәлгән.* А.Таһиров. *Нинди хикмәтедер, әби түшәгән шул урын мине май кебек эретә дә җибәрә торган иде.* Г.Гали

2) *күч.* Йомшак нәрсәне утырасы урынга яки берәр әйбер астына, йомшак булсын өчен, сузып яки җәеп салу. *Мамык түшәгем Җиргә түшәдем.* Табышмак. *Мүге белән бергә ниргә саен Шаян сүзне түши мул итеп ---.* Х.Әюп

3) *махс.* Йонны, итек яки башка киез әйбер басар алдыннан, кирәкле форма биреп җәю. *Нәҗия итек башы түши, Ул шундый җитез эшли: Аның кебек тиз түшәргә Бер кеше дә җитешми.* Ш.Маннур

4) Берәр җирне, урынны вак, сибелүчән нәрсәләр сибеп каплау, өстен шулар белән тутыру. *Шундый йола: ишек төбен Ямь-яшел мүктән түшә! Яңа кеше туган чакта Аллалар Күктән төшә!* Г.Гыйльманов. *Арыш саламнарын шактый калын түшәп, бисмилласын әйтеп каплаган иде Сәкинә баз авызын.* Г.Әдһәм

5) Тыгыз һәм тигез итеп тезелгән бүрәнә, такта, таш кебек нәрсәләрдән тезеп юл, идән, түшәм һ.б.ш. ясау. *26 июньгә каршы төндә сапёрлар, агач түшәп, сазлык аша салынган юлның ватык урыннарын төзәтәләр.* Р.Мостафин. *Урам буласы мәйданны виброкатоклар белән катоклап, ярты метр калынлыгында гравий түшиләр. Өстенә щебень, аннан бетон җәяләр.* З.Дәүләтов

6) *күч.* Кешеләрне яки хайваннарны күпләп егып салу, кыру, үтерү. *Янә гитлерчылар ябырылып килде, янә күбесен түшәп салдылар.* Ш.Рәкыйпов

**Түшәп бару** Рәттән түшәү. *Гөлсем, арбаның икенче ягындагы икенче бер кыз кебек үк, озын саплы сәнәге белән арба төбенә җайлап салам түшәп бара иде.* Н.Фәттах

**Түшәп бетерү** Түшәү эшен тәгәлләү; барлык җиргә түшәү. *Түшәп бетергәч, калган ботаклар белән*

*арбаның җил, яңгыр үтә торган ягын каплап куйды.* Г.Галиев

**Түшәп бирү** Икенче бер кешегә дип түшәү. *Минем алачык хәтле зур балконында урын түшәп бирде [хуҗа].* Т.Галиуллин

**Түшәп йөрү** Төрле урыннарга түшәү; түшәү эше белән мәшгуль булу. *Сопка итәкләре генә урыны-урыны белән агарып ята, гүя кемдер анда акбур өемнәре түшәп йөргән.* С.Шәрипов

**Түшәп кую** Түшәү эшен алдан эшләү; тиз арада түшәү. *– Күперне төзәтү генә түгел, без киләсе юлга яшел келәм түшәп куйган булырлар иде, – дидем.* А.Хәсәнов. *Минтимер Шәрипович биргән акчага асфальт та түшәп куйдылар.* Т.Миңнуллин

**Түшәп тору** Түшәү эшен башкару

**Түшәп чыгу** Башыннан ахырына кадәр түшәү. *Аннары кызып-кызып тагын сөйләп китте: – Шушы өйләрне реставрацияләп, буяп-бизәп, каралтыкураларны төзекләндереп, урамнарга агачлар утыртып, аяк астына ком белән чуерташ түшәп чыксаң, оҗмахка әйләнә бит безнең авыл!* Р.Вәлиев

**Түшәп яту** *сөйл. к.* **түшәп тору**. *Анда борын башында ике балтачы идән түшәп яталар иде.* Н.Фәттах

**Түши башлау** Түшәргә керешү

**ТҮШӘ́Ү** II *и.* Җылылык, йомшаклык һ.б.ш. максатлар белән берәр җиргә салынган катлам, пласт. *Яз көне, биоягулыкны селкеп өйгәннән соң, аны тоташ түшәү рәвешендә, яки бер метр киңлектәге түтәлләр итеп салалар.* Яшелчәчелек

**ТҮШӘҮЛЕ** *с.* 1) Түшәмәсе булган, өслеге берәр каплама белән ныгытылган. *Безнең юллар таш түшәүле, Казан юлы казылган.* Җыр

2) Түшәлгән, җәелгән, ятар өчен әзер (урын-җир тур.). *Солдатның ятыр ястыгы бөтен җирдә түшәүле.* Мәкаль

**ТҮШБА́У** *и. диал.* Чөелдерек

**ТҮШЕЛДЕРЕК** *и.* 1) *к.* **күкрәкчә**. Төсле тасмалар, ука һ.б.ш. белән бизәп тегелгән, күлмәк өстеннән киелә торган хатын-кыз бизәнү әйбере

2) *к.* **түшлек** (*3 мәгъ.*)

**ТҮШКӘ** *и. рус* Тиресен тунап яки йонын йолкып, эчен чистартып, ит буларак ашарга әзерләнгән кош яки хайванның бөтен гәүдәсе. *Ә хуҗа кешегә ара-тирә берәр түшкә сарык ите алып кайтырга гына ярыйдыр, шәт.* В.Нуруллин. *Бер дә бер көнне Чыңгыз Мусин кульъязма җыентыгын, шуңа өстәп өч литрлы бал, бер каз түшкәсе алып, Казанга килеп чыга.* Ш.Маннапов

**ТҮШКӘЛЕ** *с.* 1) Түшкәсе белән булган; түшкәләрдән торган. *Түшкәле ит*

2) Түшкәсе алда килгән сыйфатта күрсәтелгәнчә булган. *Таудай түшкәле үгез.* Ш.Галиев

**ТҮШКӘ́-ТҮШКӘ** *с.* **1.** Түшкә рәвешендәге, тулы түшкә формасындагы. *Әтисе сайлаган институтка иң беренче мичкә-мичкә бал, түшкә-түшкә ит озатылды.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Түшкәләп, түшкәләре белән, тулы түшкәләр рәвешендә. *Түшкә-түшкә озату*

**ТҮШКЕ** *и.* Түшкә кидерелә торган; түшкә беркетелә торган. *Түшке аелның батканын иясе белмәс, ат белер, ирегетнең кадерен ага-эне белмәс, ят белер.* Мәкаль

**ТҮШЛЕК** *и.* 1) Алъяпкыч һ.б.ш.ның күкрәк турысы. *Биленә түшлексез ак алъяпкыч бәйләгән официант кыз безнең якка әйләнеп карамады.* Н.Фәттах

2) *этн.* Тәңкәләр тезеп ясалган изү (элек аны хатыннар түшләренә киеп йөргәннәр). *Базарларга бардым, тәңкә алдым, Хәситәгә түгел, түшлеккә.* Җыр. *Көмеш өрфия тәңкәләр тезеп ясалган түшлекләр --- барысы да [солдатларга] китте.* Х.Кәрим

3) Җигүлектә, атның корсак астыннан үткәреп, бер тәртәдән икенче тәртәгә бәйләп куела торган каеш я бау; түшелдерек, бавыргалык. *Мөнирҗан Күкбияне туктатып, түшлеген тарттырып бәйләде, камыт бауларына күз төшерде.* Н.Әхмәдиев. *Яхшы атлар үрдән әкрен төшә, Түшлек бавын күкрәк белән тыеп. Үр менгәндә тойган авырлыкны Тагын бер кат йөрәк белән тоеп.* Н.Акмалов

**ТФИТ** *иярт.* Сызгырганда чыккан тавышны белдерә; фьют. *Көтүче тфит дип сызгырып җибәрде*

**ТФҮ** *иярт.* **1.** Төкергәндә чыккан тавышны белдерә. *Мәңге кипмәс, мәңге сөртмәс төкерегем сиңа истәлек булсын, тфү.* Г.Кутуй. *Тфү дип төкереп китте.* М.Мәһдиев

**2.** *ы. мәгъ.* 1) Сөйләүченең берәр кешегә, җанлы-җансыз нәрсәгә һ.б. кимсетүле, җирәнүле мөнәсәбәтен яки ачуын белдерү өчен кулланыла. *Тфү, җирәнгеч, әле ярый башка киткән вакыт булмады.* Г.Камал. *Әнкәсенең тагын да катырак ачуы чыкты: – Тфү, киребеткән нәмәрсә!* Р.Батулла. *Тфү, мин сине егет солтанына санап йөргән булам тагын.* М.Әмирханов

2) Әйткән сүздән кире кайтуны аңлата. *– Безнең өй түгел бу, – диде Торымтай, икеләнеп. – Әллә яшен ташы төшкәнме соң, тфү, тфү! – Сөйләнмә!* Н.Фәттах. *Тфү, тфү, үземә күз тидерә күрмим тагын.* Ф.Яруллин. *«Тфү, тфү, күз генә тия күрмәсен, Ходаем», – диде.* Ф.Җамалетдинова

**ТФҮЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тфү дип төкерү. *Тфүләп йөрүне кем дә булдыра аны, эшләп күрсәтергә кирәк!* М.Мәһдиев

2) *күч.* Тфү-тфү дип тәүбә итү. *– Тфүләүдән башканы белмисең инде, һаман шул булыр синең, – дип сукранды әтисе.* Казан утлары

**Тфүләп алу** Бер тапкыр тфү дию яки тфү дип төкерү. *Карт үзе дә ялгышлык белән генә ычкындырган булырга кирәк, башын чайкап, тфүләп алды.* Г.Толымбай

**Тфүләп тору** Озак вакыт дәвамында тфүләү; һаман саен тфүләү. *Тфүләп торма әле монда, бар, эшеңә ашык.* И.Нуруллин

**ТЧ** *ы. к.* **тс**

**ТЫБЫРСЫК** *с.* 1) Бер урында басып тора алмыйча, тыпырчынып торган; елдам. *Шаталакның теле уйный, тыбырсыкның арты уйный.* Мәкаль

2) Нинди дә булса эш эшләргә ашкынып торучан, тиктормас, тынгысыз; кыбырсык. *Тыбырсык кеше*

**ТЫБЫРЧЫК** *с. к.* **тыбырсык**. *Тыбырчыктан туң артык.* Мәкаль

**ТЫБЫРЧЫНУ** *ф. сөйл. к.* **тыпырчыну**. *Арыганчы тыбырчынып еланган да, арыгач, изелеп кителгән.* Г.Толымбай

**Тыбырчына башлау** Тыбырчынырга тотыну. *Гөлчирә ычкынырга икенче тапкыр тыбырчына башлауга, Хушият карт дога укырга кереште.* М.Мәһдиев

**Тыбырчынып карау** Тыбырчынып берәр нәтиҗәгә ирешергә тырышу. *Гайшә апа башта үзенең җиңелүенә риза булмый тыбырчынып карады.* Ә.Фәйзи

**ТЫГУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса берәр әйбер эченә яки әйберләр арасына, астына кую, кертү, салу, кыстыру. *Үзара киңәшкәч, болай итәргә булдылар: башта, сынап карар өчен, тегенең портфеленә алтын сәгать тыгалар.* Г.Әпсәләмов. *Әгәр син миңа кайчан да булса, мин синеке, дип әйтергә карар итсәң, конверт эченә тыгып, миңа шул каурыйны сал.* М.Мәһдиев

2) Берәр нәрсәгә кадау, чәнчү. *Димәк, Нур Сафа дигәннәре – кешегә пычак тыгар алдыннан да назлы итеп елмая белүче бандит шикеллерәк нәрсәдер.* Ф.Баттал. *Күпме генә кыйнасалар да, ике кабырга арасына пычак тыгып тотсалар да, салкын, юеш идәннәрдә кан түкереп ятканда да, ул үз уеның очын югалтмады, аңыннан, зиһененнән язмады.* Г.Гыйльманов

3) Көрәк, сәнәк кебек эш коралларын һ.б.ш. җиргә (туфракка, комга һ.б.ш.га) кертү. *Казыйсың: көрәгеңне беткәнче җиргә тыгасың да каерып атасың.* М.Мәһдиев

4) Тишекне яки тишеге булган әйберне нәрсә белән да булса томалау, каплау. *Бик шау-шулы булды: минем колак авыртып, мамык тыгып йөргән чак иде.* Н.Нәҗми. *Уйланып утырган Джиммины кинәт тотып ала, аркан белән бәйли, авызына чүпрәк тыга.* Г.Каюмов

5) Берәр әгъзаны тәрәзә, ишек, капка кебек нәрсәләр аша чыгару яки кертү. *– Атам, тукта! – дип кычкырды ул, тәрәзәдән башын тыгып.* Ф.Яруллин. *Мин машина кабинасыннан башны тыгып, кирәк урамны сорыйм.* З.Зәйнуллин

6) *сөйл.* Берәр әйберне игътибарсызлык аркасында яки ашыгычлык белән кая да булса кую, кыстыру. *Адресын әллә кая илтеп тыктым бит шул чак.* Г.Гобәй. *Картайдык бит инде, хәтер начар. Икенче җиргә тыгып оныткан-мындыр.* Ф.Баттал

7) *сөйл.* Тиз табылмасын өчен, әйберне берәр җиргә кую, яшерү. *Мин, ераграк тыгып куйган акчамны чыгарып, вакыт үтсен өчен, буфетка кереп утырдым.* А.Шамов

8) *сөйл.* Акчаны, байлыкны һ.б.ш. берәр нәрсә өчен сарыф итү. *«Һаман саен бу эшкә акча тыгу урынсыз, керем булмаячак», – дип, дусларым берсе артыннан берсе киттеләр.* А.Сабирова

9) *күч.* Кешене үз теләгеннән башка берәр кая җибәрү, кертү, урнаштыру. *Илгә, хөкүмәткә каршы сүз әйткәннәрне юләрләр арасына илтеп тыгалар да югалталар икән.* А.Гыйләҗев. *Тырышып эшләп йөрүчеләрне төрмәгә тыгу заманнары түгел хәзер!* М.Хуҗин

10) *күч.* Сүзгә, әңгәмәгә нинди дә булса фикерне, мәсьәләне яисә сүзләрне тиешле-тиешсез урында катнаштыру, кыстыру, кертү. *Кыз, --- иске мирза гадәтенчә, бик күп русча тыгып сөйләп бирде: – Беләм мин, зәһәр нәрсә ул Гәүһәрегез!* Г.Ибраһимов. *Яшьләр газетасына безнең исемнәрне тыгып мәкалә язган кеше Илдускамы?* М.Мәһдиев

11) *күч. иск. Сан, исәп* сүзләреннән соң килеп, берәр сан исәбенә кертү, искә алу. *Әллә нинди күңелле, әллә нинди рәхәт булырлык нәрсәләрне санга тыкмыйлар.* Ф.Әмирхан. *Узган еллар өчен биш таякны исәпкә тыкмыйсыз икән, бу гаделлек булмас.* Ә.Фәйзи

12) *күч.* Кешенең игътибарсызлыгыннан яки шул өлкәдә мәгълүматсызлыгыннан файдаланып, сиздермичә, алдап, берәр яраксыз, кирәксез яки сыйфатсыз нәрсә бирү. *Югыйсә сиңа беренче сорт дип икенче сортны тыгарлар, ә син шап та шап – тамга сал.* Г.Әпсәләмов

13) *күч. туп.* Комсызланып, артык күп ашау (кешенең ашавын яратмаганда әйтелә). *Киләдер күп кодалар, абжур кебек тыгалар. Коданың хәлен белмиләр, актык маен сыгалар.* Ш.Мөхәммәдев. *Менә гуж, кай җиренә тыга бу чаклы?.. Күпме ашар икән бу?* Н.Исәнбәт

**Тыга бару** Булган берсен тыгу; рәттән тыгу

**Тыга башлау** Тыгарга керешү. *Кулын кесәгә тыга башлады.* Н.Акмал. *Кулын эченә тыга башлаган җиреннән туктады да, тартманы әйләндереп, эчендәге бар нәрсәне җиргә бушатты.* З.Зәйнуллин

**Тыга бирү** Бернигә карамый тыгуны дәвам итү; тагын тыгу. *Кунаклар килгәнгә дә исе китмичә, һаман тыга бирде.* Казан утлары

**Тыга тору** Берәр эш-хәлгә кадәр тыгу

**Тыга төшү** Бераз гына тыгу; тагын да күбрәк тыгу. *Хуҗалык эшләрендә йөрүче тоткын тәрәзәдән башын тыга төшебрәк икенче тапкыр кабатлагач кына үзенә дәшүләрен абайлап алды.* И.Сираҗи

**Тыга язу** Чак кына тыкмый калу. *– Һичьюгы, бу покрышкаларны салдыр әле, агай, – дип ялвара башлаган идем, таягын авызыма тыга язды: – Урам уртасында машина сүтәргә ярамый.* Ф.Баттал

**Тыгып алу** Бик аз вакытка тыгу. *Һава, диңгезгә тыгып алгандай, дымлы вә юеш, аяк асты тездән су һәм пычрак иде.* Г.Ибраһимов. *Ашыйсым килгән саен, чаба-чаба барган хутка, әнә шул янчыкка телемне генә тыгып алам.* Ф.Баттал

**Тыгып бару** Булган берсен рәттән, эзлекле рәвештә тыгу. *Без дә тик тормыйбыз, бодай башакларын үзебездән күрше апаларның көлтәләренә тыгып барабыз.* Р.Вәлиева

**Тыгып бетерү** Барысын да тыгу. *Акчасын ул түйгә тыгып бетерә язган.* Ә.Фәйзи. *Исемлеккә һәммәбезне дә тыгып бетерә алмаслар!* З.Зәйнуллин

**Тыгып җибәрү** Тиз генә, кисәк тыгу. *Менә бер кесәсенә кулын тыгып җибәргән иде, кулына әлеге алтын дага тиде.* Әкият. *– Мал табибын чакырткан идек, тәненең шешкән урынына калын энә тыгып җибәрүе булды, сасы үлек ага башлады, – дип сөйләде бер танышыбыз.* Г.Хуҗиева

**Тыгып карау** Сынау, нәрсәнедер белү, аңлау өчен тыгу. *Гамил иң соңыннан чишенеп бетсә дә, суга аягын беренче булып тыгып карады.* А.Тимергалин. *Ул тизлекне беренчегә*

*тыгып карады – кермәде, икенчегә тыгып карады – кермәде.* Р.Батулла

**Тыгып кую** Тыгылган хәлгә китерү. *Салкын тәнеңне кара җир астына тыгып куялар, ялгыз каласың.* Д.Заһидуллина. *Шул мәлне бирәү үзенең борын кулъяулыгын аның авызына тыгып куйды.* З.Мәхмүди

**Тыгып тору** Билгеле бер вакытка тыгу; сөйләү моментында тыгу. *Син колакларыңа бармакларыңны тыгып тор.* К.Тинчурин. *Аны мич алдындагы утлы күмергә тыгып торды.* А.Хәсәнов

**ТЫГЫ** *и. диал.* Тавык кунаклый торган колга; кунача. *Тавыклар барысы да тыгыда инде бу вакытта.* М.Вәлиев

**ТЫГЫЗ** *с.* **1.** 1) Бер-берләренә бик якын һәм нык берекkән кисәкләрдән торган. *Җирнең өс кабыгы, эчендәге матдәгә караганда тыгызрак булганга күрә, акрынрак кысыла.* Ф.Әмирхан. *Төн уртасында, кала урамнарында тыгыз карны шыгырдатып җитәкләшеп барганда, бу ышаныч арткаaннан-артты.* М.Маликова

2) Бер-беренә бик якын торган; еш, куе. *Әле ул вакытта авыл мәчете мәктәпкә әйләндерелмәгән иде, картлар тыгыз колонна булып басып, тәкбир әйтеп, урамнан узалар, гает укырга мәчеткә җыелалар иде.* М.Мәһдиев. *Әнә, тыгыз әйләнә булып, бер көтү егет-җилән тезелеп баскан. Подъезд сакларга куйганнар диярсең.* Ф.Җамалетдинова

3) Кысан, кысрык, тар; буш урыны булмаган яки бик аз калган. *Һавасыз тыгыз зал эчендә, мәдрәсә яшьләренең үпкәләрендәге авырлыкка карамастан, йөзләре җанлана бара, башка чакта хәлсез үлек карашлы булган күзләрендә бу сәгать ялкын ялтырый иде.* Г.Ибраһимов

4) Шыплап тутырылган, эче тулы булган; тыгызлап тутырылган. *Арбада тыгыз капчык өстенә атланып утырган Җәмил, атны тагын да ашыктырмакчы булып, кулына чыбык алды.* Н.Фәттах. *Троллейбус төеп тутыргандай тыгыз иде, кергән кешеләрне төрле яктан китереп кыстылар.* М.Маликова

5) Эче тулы булган, тук, мул (башак, бөре һ.б.ш. тур.). *Иген кырларыбызда тыгыз башаклы алтын бодай [үсә].* Г.Гобәй. *Тыгыз кабыклары эченнән булачак тәңкә-яфраклары да баш төртә.* Казан утлары. *Уңышлар үссен өчен, Тып-тыгыз орлыклар тулып, Башаклар пешсен өчен, Яле миңа әйтегез, Язын нишләргә кирәк?* Нәүрүз бәйрәме

6) Еш итеп тукылган (тукыма тур.). *Шулай да сыңар күзе белән генә ул чибәр кызның --- сары җирлеккә кызыл чияләр төшерелгән тыгыз тукымадан тегелгән һәм сылу тәнне йомырылап кысып торган тар, кыска киемен, күкрәкчәсен күреп калды.* Н.Фәттах. *Бүлмәне тыгыз, ачык соры тукыма белән тышланган, юан аяклары бизәкле агачтан эшләнгән диван, ике тирән кәнәфи --- бизи.* Т.Галиуллин

7) Таза, нык; йомшармаган, сәлперәймәгән (тән тур.). *Җизнәсенең тыгыз мускулларына Зөһрә яшертен генә сокланып карап куйгалады.* Ф.Яруллин. *– Тик кенә ята алмыйсың инде син, – диде хатын олы, тыгыз, кайнар тәнгә сарылып.* Т.Галиуллин

8) Көчле; көчле басымлы һәм кызу хәрәкәтле (агым, җил һ.б.ш.). --- *җил ихтыярына бирелеп каядыр юлдан читкә китеп бармас өчен, шактый көч куярга туры килде: тыгыз һава дулкынын чын-чынлап күкрәк белән ерып барырга туры килде.* Н.Фәттах. *Сикерүгә үк, тыгыз җил агымы аны артка таба чөеп җибәрде.* Р.Вәлиев

9) Көчле; нык сизелерлек (ис тур.). *Җете җылы кояш астында алтынсыман басулар тынып калган, дөньяны куе, тыгыз ис – кырау тигән бәрәңге сабагы исе баскан.* М.Мәһдиев

10) Башка эш белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирми, вакыт калдырмый торган, ашыгыч, күп (эш тур.). *Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча, карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.* Ә.Еники. *Эшең тыгыз икәнен беләм, улым.* З.Зәйнуллин

11) *күч.* Турыдан-туры, ныклы, якын (бәйләнеш, багланыш). *Башкортстан язучылары, композиторлары, артистлары белән бик тыгыз иҗади элемтә урнаштырылды.* К.Тимбикова. *Ләкин син миңа шушы Яңавыл станциясендә яшерен пост булдыр һәм ул пост белән даими тыгыз элемтә тот.* В.Нуруллин

12) *күч.* Аз күләмгә күп сыйган, бай, мул (фикер, сюжет һ.б.ш. тур.). *Кыска, әмма тирән һәм тыгыз эчтәлекле кереш мәкалә дә аның тарафыннан язылган.* Х.Миңнегулов. *Һәр строфа, һәр куплет, күп вакытта һәр юл мөстәкыйль яшәрдәй тыгыз фикерле.* Р.Батулла

13) *күч.* Ашыгыч эшләр күп булган, киеренке (вакыт тур.). *Аларның гомере ничектер вакыт ягыннан тыгыз: көне атнага, атнасы айга туры килерлек.* Х.Миңнегулов. *Хәзер яшь галимнең вакыты тыгыз, бала тугач та әти кеше улын кулына алмады, төннәрен елап бимазалый дип, өйдә дә сирәк кунды.* Н.Гыйматдинова

14) *күч.* Акчаны чамадан тыш кысып тотучы, саран, кысмыр. *Әти – бик тыгыз кеше*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер-беренә якын килеп, бер-беренә якын торып, кысылып; еш булып. *Агач арасында биек булып тыгыз үскән үләнне йолкып, кочаклап, куыш эченә китереп салдылар.* Г.Якупова. *Зур булмаган шул урында бер-беренә бик тыгыз утырган йөзгә якын корылма калдыклары табыла.* Татар, уян!

2) Кысан, кысрык. *Әлбәттә инде, ягъни җәмәгатьсез кешегә артык тыгыз булмас дип уйлыймыз, әйе...* Ш.Камал

3) Бер буш урын да калдырылмыйча. *Ул аның янына үтергә чамаласа да, зал бик тыгыз тулган иде, үтә алмады, шунда, тәрәзә яңагына сыенып, тыңлый башлады.* Г.Ибраһимов. *Мич кырыенда, идәндә, тыгыз итеп тутырылган спортчылар рюкзагы.* Г.Әпсәләмов

4) Бернинди буш ара яки ярык калдырылмыйча. *Аның танау озынлыгы гәүдәсенең өчтән бере кадәр, тешләре очлы һәм казналыкта бик тыгыз урнашкан.* Хайваннар дөньясы

5) Кысып, каты итеп, еш итеп. *Нургали аны бер күрү белән дөрләп кабынды: унҗиде яшьлек кызның тыгыз итеп үргән озын чәч толымнары, сызылып кына киткән нечкә кара кашлары --- егетнең һушын шундый алды ки, кызга авылына кайтып китәргә дә*

*ирек бирмәде.* Ә.Еники. *Машинаның аптечкасында бинт белән йод калган икән, Әнисә яраны эшкәртеп, тыгыз итеп бәйләде.* Т.Галиуллин

6) Аерылмаслык, нык итеп. *Алай гына да түгел, безнең күрше республикалар, өлкәләр бер-берсе белән шулкадәр тыгыз бәйләнгәннәр, аларны инде хәзер берничек тә аерып алырлык түгел.* Р.Миңнуллин

◊ **Тыгызга килү** Хәлнең бик авыр, кыен булуы, эшнең киеренкелеге турында. *Бу җәйне Мостафинның эшләре аеруча тыгызга килде.* Ә.Еники. *Ә миңа тыгызга килә башласа, үзем язармын, дөнья хәлләрен белеп булмый.* С.Баттал. **Тыгыз(га) туры килү** *к.* **тыгызга килү**. *[Танклар] кичә аталаган булсалар, безгә бик тыгыз туры килгән булыр иде.* И.Гази. *Ләкин бәрәңге алу башланды гына, алда чөгендер тора, тыгызга туры киләчәк.* М.Маликова. *Кыскасы, быел безгә ачлык янамаса да, шактый тыгызга туры килүе ихтимал.* Шәһри Казан. **Тыгыз тоту** Ашыктыру, тизләтү

**ТЫГЫЗАЙТУ** *ф. к.* **тыгызлау**. *Мендәрне тыгызайту. Эшне тыгызайту*

**ТЫГЫЗАЮ** *ф. к.* **тыгызлану**. *Һава, тыгызаеп, безне җирдән аерды һәм өскә күтәрә башлады.* С.Баттал

**ТЫГЫЗЛАГЫЧ** *и. к.* **тыгызлаткыч**. *Люк астындагы резин тыгызлагыч ябышып калгандыр.* З.Зәйнуллин. *Элек комбайн артыннан саламны җыеп эскертләү зур көч сораса, хәзер комбайн артыннан ук басуга җыйгыч һәм тыгызлагыч техника керә.* Якты юл

**ТЫГЫЗЛАНДЫРУ** *ф. к.* **тыгызлау**. *Эш көнен тагын да тыгызландыру турында көрәш алып барырга кирәк.* А.Алиш

**ТЫГЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса вак кисәкләренең бер-берләренә якынаюы, керешүе нәтиҗәсендә, тыгызрак, куерак, катырак хәлгә килү. *Салам тыгызланып каткан, күшеккән куллар шуа, һич йолкып булмый.* Р.Батулла. *Механик юл белән яхшылап баскалаганда, бетон измәсе тыгызланып урнаша.* Төзү материаллары

2) Кешеләрнең бик күп, тиешеннән артык керүе, урнашуы яки әйберләрнең күп куелуы аркасында тыгызлык хасил булу, кысанлану (торак, транспорт һ.б.ш. тур.). *Димәк, җир тыгызлана, яшәү пространствосы кысыла, кояш астындагы урын өчен көрәш-дау көчәя, терсәккә терсәк ныграк тия, йөрәкләр ярсурак тибә.* Р.Фәйзуллин. *Ул, борылып, өске ут кабызылган булса да, шактый караңгы, борынгы шкафлар белән тыгызланган алгы бүлмәгә, аннары зал ягына таба атлады.* М.Маликова

3) Бер-беренә тиеп, орынып торырлык дәрәҗәдә, бик аз гына ара калдырып якын урнашу; кысылу. *Алар артында моңарчы митингларга йөрми торган Вафа хәзрәт шәкертләре, байтак приказчиклар, бу тирәнең итекче, тегүче, бүрекче кебек вак һөнәрчеләре, тыгызланып, саф-саф утыралар.* Г.Ибраһимов. *Шушы минуттан барысы да: караңгы, салкын клуб эче дә, янәшәсендә генә тыгызланып утырган тамашачылар да, хәтта гел күз алдында селкенеп торган Яруллин да аның өчен югалган кебек булды.* Ә.Еники // Төрле әйберләр, затлар арасында ачыклык калмау (ара якынаю һ.б.ш. тур.). *Кояш яктысында иркәләнгән сөңгеләрнең, байракларның аралары тыгызланды.* К.Нәҗми

4) Ешаю, куелану. *Каршы якта исә, кызыл балчыгы коелып торган текә яр өстендә, тыгызланып, бер-берсенә сыенып, карамалар, юкәләр, усаклар тынып калган, алардан арырак, барысыннан да биегрәк булып, бик зур ялгыз чыршы калкып утыра иде.* Н.Фәттах. *Бакчаңда бетерсәң, аланнарда үсә, буш урын таба да тыгызланып үрчи, яңа орлыклар очыра!* Ш.Галиев

5) Нәрсә дә булса арту, күбәю, баю. *Ләкин бертуктаусыз җанын борчып торган ниндидер ярсулы ачыну аның йөрәгендә килгәннән бирле тыгызлана, һаман күп итеп сөйлисе, бушанасы килеп тора.* Ә.Еники. *Дөнья матурая төшкән кебек күренә: ничектер тыгызлана, тулылана төшкән кебек.* Х.Туфан

6) *күч.* Тарсыну, сыешмау, кемнедер артыксыну. *Ә инде дусларының ата-аналары тыгызлана башлагач, аңа фәкать күп фатирлы йортларның җылы подвалларында гына урын кала.* Ватаным Татарстан

7) *күч.* Бик күбәю, киеренкеләнү; кысылу (эш, вакыт тур.); берәр эш белән бик мәшгуль булу. *Тыгызлана Вакыт, Тора-бара нишләр?* Р.Миңнуллин

8) *күч.* Берәр нәрсә эшләргә ашыгу, ашкыну. *[Ул] иптәшенең хәрәкәт һәм кыланышында әллә нинди бер аптырау һәм тыгызлану күрә.* Ш.Камал

9) *күч. сөйл.* Саранлану; акчаны санап, чамадан тыш кысып тоту. *Акча мәсьәләсендә шундый инде ул... гомер буе тыгызланып яшәде.* М.Вәлиев

10) *күч.* Эчтәлеге баю (фикер, сюжет һ.б.ш. тур.) *Зыятдинованың шигырьләре күзгә күренеп ныгый, саллылана, тыгызлана.* Р.Миңнуллин

**Тыгызлана бару** Вакыт үткән саен ныграк тыгызлану. *Әмма һәр үсмерне билгән бер уй – кызлар турындагы уй – көннән-көн ныгый, тыгызлана барды, һәр егет үзенә ошаган кызны эзли, таба, күзәтә, бар ягын да Альберт калыбына куеп тикшереп карый.* Р.Батулла. *Мөхәммәтшинның эш режимы елдан-ел тыгызлана гына бара.* Р.Миңнуллин

**Тыгызлана башлау** Тыгызлану билгеләре күренү. *Зөфәрнең кычкырып көләсе килде, күкрәгендә тантана һәм ярсу тыгызлана башлады, ашыгудан кулларын күлмәк җиңенә кертә алмыйча азапланды.* Ә.Еники

**Тыгызлана тору** Эзлекле рәвештә тыгызлану. *Карыйсың: таң чыкларында коенып, кояш нурларын сеңдереп тыгызлана торгач, алар инде сабый йодрыгы хәтле булып өлгергәннәр.* Р.Низамиев

**Тыгызлана төшү** Тагын да ныграк тыгызлану. *– Ягез әле, кызлар, тыгызлана төшегез, – дип, арага кереп утыра да ни өчендер кинәт кенә елый башлаган Радийны, әллә чеметеп куя инде, тез өстендә тыпырдатып яки куенында селкеткәләп юатырга керешә һәм күзләрен челт-челт йомгалый.* Т.Нурмөхәммәтов. *Хаҗга килүчеләр белән шәһәр тулгач, эшләре тыгызлана төшкән.* Татар әдипләре

**Тыгызланып бару** *к.* **тыгызлана башлау**. *Эш бик тыгызланып барганга*

*күрә, [Гарифуллалар] эш калдырып авылга кайтып йөрми[ләр].* М.Гафури

**Тыгызланып бетү** Тәмам тыгызлану; тыгыз хәлгә килү. *Бакча үсемлекләр белән тыгызланып бетмәгән булса, җилләтелсә, аңарда авырулар озак тормый.* Шәһри Казан

**Тыгызланып калу** Ниндидер тәэсирдән соң тыгызлану; билгеле бер вакыттан соң тыгызлану. *Ул да утыргач, университетның актлар залы тәмам тыгызланып калды.* Ф.Яхин

**Тыгызланып килү** Акрынлап, азазлап тыгызлану. *Улының тыгызланып килгән мускулларын күреп бик сөенде Габдулла.* Казан утлары

**Тыгызланып китү** Кинәт тыгызлану; күзгә күренеп тыгызлану. *Камали агай да кергәч, тар бүлмә тулып, тыгызланып киткәндәй булды.* Ә.Еники. *Элек аяклары камыр кебек иде, әллә еш бастыргалап торганга, әллә тege арбада хәрәкәтләнеп йөргәнгә, ботлары тыгызланып китте.* Ф.Яруллин

**Тыгызланып тору** Тыгызланган хәлдә булу. *Ахырда ул башын кинәт тезләре өстенә сала һәм, һичбер нинди тыелусыз, юка пальтосы аша түгәрәкләнеп, тыгызланып торган иңбашларын калтырата-калтырата елап җибәрә.* Ә.Еники. *Ярымшәрә тәне тулып, мускуллары тыгызланып тора.* Ф.Яхин

**ТЫГЫЗЛАТКЫЧ** *и. тех.* Балчык, ком һ.б.ш.ларны тыгызлый, баса торган җайланма. *Салам тыгызлаткыч, төяп бушаткыч агрегат сатып алган да саламны хәзер шуның ярдәмендә ферма янына ташыта.* Туган як

**ТЫГЫЗЛАТУ** *ф. йөкл. к.* **тыгызлау**. *Машина-машина чыбык-чабык салдык, шәпләп таптаттык, тыгызлаттык.* М.Вәлиев. *Алкоголь ашказаны стенасын да тыгызлата.* Ватаным Татарстан

**ТЫГЫЗЛА́У** *ф.* 1) Көпшәгрәк, йомшаграк әйберне басып, төеп, пресслап, тыгыз, каты хәлгә китерү. *Рабига --- Габдулланың аркасын, ябык җилкәләреннән тотып, үрдәк мамыгыннан тыгызлап тутырылган шул мендәргә терәттерде.* М.Хуҗин. *Көндез өйгән печәнне шактый гына тыгызлагач, икесе ике якка ятып, тынып калдылар.* Ф.Яруллин

2) Булган араларын бетерү, тыгыз итү; нык якын китереп, ара калдырмыйча ябу, томалау. *Ишек бикле, тәрәзә тыгызлап ябылган булса да, идәндә, тәрәзә төпләрендә, киштәдәге китапларга бармак калынлыгы соры тузан яткан.* А.Гыйләҗев. *Ирек имән бусагадан өй эченә атлады; артына борылып, ишекне тыгызлап ябып куйды.* Г.Рәхим

3) Күп урын алу, кысан итү; кысанлык тудыру. *Сыюын сыя, тик кирәксез нәрсә белән аны тыгызлау артык.* Ф.Яруллин. *Галинең квартирын ары таба тыгызлауга юл калдырмавыгызны сорый.* Ф.Баттал

4) Еш итү, еш урнаштыру. *Әдәби журналдагы текә чәчле бакыр башлы озын егет Хушият картның шакмаклы дәфтәргә тыгызлап язган кульязмаларын тегеләй әйләндерде, болай әйләндерде.* М.Мәһдиев

5) Бер урынга күп итеп урнаштыру, тутыру. *Шуннан соң, «телячий» вагонга тыгызлап тутырып, Мәскәүгә озаттылар.* З.Зәйнуллин

6) *сөйл.* Берәр нәрсә эшләргә кыстау, көчләү. *Ахыр, атасы тыгызлагач, икърар кыйлды: «Алдым, әткәй, ләкин мин урынына салып куйдым», – диде.* К.Насыйри. *Солдатны тыгызлап, бимазалап тормасаң, бик тиз үшәнләнә ул.* Х.Камалов

7) *куч.* Комачаулау, ирек бирмәү; чикләү. *Пажалысты, тыгызласам, чыгарга мөмкин.* Г.Кутуй. *Йөрәге сулык-сулык тибә, сулыш алуын тыгызлап, күкрәген нидер кыса, эче яна иде.* Х.Камалов

8) *куч.* Арткарак күчәргә, чигенергә мәҗбүр итү, кысрыклау. *Һәм менә декабрь урталарында безне кызгандылар ахры, башкаларны тыгызлау хисабына, тыгыз бүлмәләрне тагын да тыгызлап, безне аерым-аерым бүлмәләргә урнаштырдылар.* А.Алиш

**Тыгызлап алу** Бер тапкыр тыгызлау; тиз арада тыгызлау. *Кан кызгач, яңа көч белән печәнне тыгызлап алдылар.* Ф.Яруллин

**Тыгызлап карау** Тыгызларга тырышу. *[Извозчик] атын никадәр сугып тыгызлап караса да, мескен арык вә кечкенә ат --- йөрешен бер дә арттыра алмый.* Ш.Камал

**Тыгызлап кую** Тыгызланган хәлгә китерү. *Шушы уйлар әкренләп Рифаны тынычландырды, ул урыныннан торды, тузган чәчләрен рәтләде, каешын тыгызлап куйды.* Х.Камалов

**Тыгызлап тору** Хәзер, әле тыгызлау; берникадәр вакыт тыгызлау. *Баядан бирле йөрәгемне нәрсәдер тыгызлап тора иде, бары шул, сытылып, күзләремнән агып киткән кебек кенә булды...* Ә.Еники. *Йөрәген нидер авырттырып, сулыш алуын тыгызлап тора иде.* Х.Камалов

**Тыгызлап чыгу** Барысын да тыгызлау; һәрберсен аерым-аерым тыгызлау; тулысынча тыгызлау. *Кипкәч, юлның өстен грейдер белән тигезләп, тыгызлап чыгачакбыз.* Туган як

**Тыгызлый бару** Торган саен күбрәк тыгызлау. *Тамырлар күмелә төшкәч, туфракны аяк очы белән акрынлап тыгызлый баралар.* Сабантуй

**Тыгызлый башлау** Тыгызларга керешү. *Ишектән керүчеләр тыгызлый башлагач, алар, көлешә-көлешә, кулларына кепкаларын тоткан килеш, чиркәүдән чыгып киттеләр.* Һ.Такташ. *Юк, ул саф, әнә төнлә белән, мин нык тыгызлый башлагач, ничек чын күңелдән елады.* Х.Камалов

**Тыгызлый төшү** Тагын да ныграк тыгызлау; бераз тыгызлау. *Җылы көннәрдә агач-куаклар арасындагы карны таптап тыгызлый төшәргә кирәк, дигәнне ишеткәне бар аның.* Казан утлары

**ТЫГЫЗЛЫ́ГҮЛЧӘГЕЧ** *и. махс.* Төрле матдәләрнең тыгызлыгын үлчәгәндә кулланылган приборларның (мәс., ареометр, денситометр, консистомер һ.б.ш.ларның) гомуми атамасы; *русчасы:* **плотномер**

**ТЫГЫЗЛЫК** *и.* 1) Бик нык тыгызланган, басылган, кысылган, береккән булу. *Менә әлеге басу да чисталыгы, тыгызлыгы белән шаккаттырды.* Йолдыз. *Туфракның тыгызлыгына кара син, кайчан әле шулай булганы бар иде...* Казан утлары

2) *физ., хим.* Нинди дә булса җисемнең күләм берәмлегендәге масса-

сы; массаның күләмгә нисбәте. *Монда өченче оператор махсус детонаторлы пультивант ярдәмендә чималның тыгызлык коэффициентын һәм турбулентлы магнетикасын тикшерә.* Җ.Юныс. *Тыгызлык һәм май микъдары буенча бүлү углеводород комплексларына нефть битумы яисә нефть битумы һәм мальта, аерым очракларда – мальта һәм асфальтитлар керүен күрсәтте.* Фән һәм тел

3) Кысанлык, урын азлыгы. *Анда тыгызлык: кая карама авыллар, торак пунктлар я шәһәрчекләр.* А.Хәсәнов. *Гадәттәгечә, арткы мәйданчыкта тыгызлык хасил булды, кызларның берсе, җәйлап басарга тырышып, Мортазага нык ышкылып боргаланды.* М.Маликова

4) Ныклык, тазалык (тән тур.). *Тәненең тыгызлыгы турында әйткән дә юк, иңнәренә һич тә ир-ат кулы сарылган димәссең, тач җитлеккән кузак инде менә.* М.Хәсәнов. *Җиргә иелгәндә, кызның юка костюм-чалбары аша тәненең тыгызлыгы беленеп, таза-саулыгы, яшьлек көче бөркелгән чаклары күз алдына килә.* М.Маликова

5) *куч.* Хокуклар һәм мөмкинлекләр чикләнгәнлек; кысынкылык. *Шул заманнарда мөселманнарга дин тугрысында тыгызлык булган.* К.Насыйри. *Иң явыз кеше – үзенең гаиләсенә гадәттән тыш тыгызлык кылучы кеше.* Р.Фәхретдинов

6) *куч.* Эчтәлектәге фикер тулылыгы, образ, идея һ.б.ш. байлыгы. *Ләкин сугыш турындагы әсәрләрдә В.Быковныкы кебек тыгызлык, киеренкелек юк. Сүз күп.* Ф.Яруллин. *Мин әз генә гаепләүче ягына авышып-авышып аламдыр, бәлки, ләкин өстәргә мәҗбүрмен: күләм артык зур – тыгызлык югала.* Идел

**ТЫГЫЛДЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса артык күп тутырып, үтә алмаслык итү, төяү. *Бер фикер икенче фикергә каршы килде, язгы бозлар берсе берсенә төртелеп, юлларын тыгылдырган шикелле, уйлары тоткарланды.* Х.Камалов

2) *куч.* Берәр дәлил, фикер һ.б.ш. белән тулысынча килешергә мәҗбүр итү, каршы килерлек мөмкинлек калдырмау. *Әйтеп карасыннар, китегез, авылыгыз дөрес җиргә салынмаган дип, шунда ук тыгылдырыр аларны Әхмәдулла хәзрәт: ике башлы каракош сурәте ясалган сургучлы кәгазьне борыннарына гына төртер.* И.Сираҗи

3) *күп.* Канәгатьләндерү. --- *казна угрыларының тамагын депутатлар бик шәп тикшергәндәй итеп расланган бюджет та, геометрик прогрессия белән арта торган «хезмәт хаклары» да тыгылдыра алмый, урлапмы-урлыйлар, ә һаман җитми.* Татарстан яшьләре

**ТЫГЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тыгу** (*1, 3 мәгъ.*). *Кынысына тыгылмаган әле кылыч!* К.Тинчурин. *Резина шланг эченә тыгылган тимер таяклар белән кыйнап, бөерләрен дә бик нык эштән чыгардылар: чак кына уңайсызрак кузгалып куйса да, билләре-аркалары авыртуына һич тә түзәр әмәле калмый.* Р.Мостафин

2) Берәр нәрсә эченә, арасына кулны кертү. *Кесәсенә тыгылып, кулъяулыкка төргән бер кисәк нәрсә чыгарды.* З.Зәйнуллин. *Оятсыз, кием шкафларыма хәтле тыгылды.* Н.Гыйматдинова

3) Тәрәзә, ишек һ.б.ш. нәрсәләрдән башны тышка чыгару яки эчкә кертү. *Тәрәзәдән тыгыласы түгел, ябылуга күнегә торыгыз.* К.Кәримов

4) Берәр тар аралыкка үтеп керү. *Ул ботак исә матча белән бүлмә тактасы өстендәге аралыкка тыгылып, бер башы белән түшәмгә терәлә, икенче башы йортның олы ягына (бүлмәсенә) чыгып бераз салынып тора.* М.Мәһдиев

5) Нинди дә булса бер тар урынга күпләп җыелу, өелү. *Һәркем үзенең базарга һәм мәркәзгә якын булуын теләгән, шул сәбәптән анлар бер җиргә тыгылганнар һәм бер җиргә килеп укмашканнар.* Г.Камал

6) Берәр тар аралык, юл үтмәс булу, томалану. *Юынгычыбыз күптән тыгылган, һәм юынтык сулар агып чыгып китә алмый җәфалый иде.* Ф.Яруллин. *Бусы инде боз тыгылу дигән сүз!* М.Вәлиев

7) Тар урында терәлеп калу, бөялү. *Коры азык тамагына тыгыла, һәм кеше шулай үләргә дә мөмкин.* Х.Камалов. *Ул бу хәләндә бугазына әйбер тыгылып, сулый алмый торган бульдогка охшап калган иде.* Р.Сәгъди

8) *сөйл.* Авызга берьюлы күп ризык тутырып, аны тамактан үткәрә алмау. *Атның икенчесе печәнгә тыгыла.* Әкият. *Аны Галиянең кыстыбыйга тыгылып ыкы-мыкы килеп торуы да кызыксындырмый.* Л.Ибраһим-Вәлиди

9) Авырган вакытта яисә нәрсәдер тәэсирендә, аркасында борын, колак һ.б.ш.ның үз функцияләрен тулысынча башкара алмавы, өлешчә ябылуы, каплануы. *Ну, күрәсез, минем бөтен җирем дә үз урынында, аяк-куллар да, тик баш кына яман шаулый. Һәм колакларым бераз тыгылган, шулаймы?* Ә.Еники. *Әркәшәнең һәрвакыт борыны тыгылган була, һәм ул бервакытта да борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнми иде.* М.Мәһдиев

10) **тыгыл** *туп. боерык ф. форм.* Комсыз кешене тиргәп әйтелә. *Ашасаң – аша, ашамасаң, тыгыл!* Д.Салихов. *Сарай артындагы әллә кайсы урыннан шыпырт кына бер капчык бодайны алып чыкты да, карганып, аны арбага ыргытты: – Мә, тыгыл!* Д.Бүләков

11) *куч.* Тиешле-тиешсезгә берәр эшкә, әңгәмәгә катнашу, тыкшыну, кысылу; сорамаганда киңәш бирү, акыл сату. *Яшьләр эшенә тыгылма инде.* А.Алиш. *Син Әкбәр эшенә тыгылма, академик, үз эшеңне кара.* И.Юзеев. *Нигә минем шәхси эшләремә тыгыласың?* Р.Батулла

12) *куч.* Нык әсәрләнүдән, тәэсирләнүдән елыйсы килү, сөйләшә алмау. *Кызның тамагына нидер килеп тыгылган, күзе яшьләнергә башлаган кебек хәл булды.* Г.Ибраһимов. *Яшемә тыгылып сүземне дә әйтә алмыйм.* К.Тинчурин. *– Юк, кирәк түгел, – диде Мәсрүрә, яшенә тыгылып, – минем күңелемне кузгатма.* М.Мәһдиев // Сөйләү сәләтен вакытлыча югалту, тотлыгу. *Фәрдәнәнең тавышы бугазында тыгылып өзелде.* Х.Камалов

13) *куч.* Нинди дә булса хискичереш, тойгы, сәбәп һ.б. аркасында сулу кабу, буылу, иркен сулыш ала алмау. *Зыя, баягы иптәше Госман*

*белән тагы очрашып, аның фатирына бару өчен чанага утырырга гына хәзерләнгәннәр иде; бик арып, ахылдап беткән бер малай килде дә, тыгылатыгыла: – Кочкә-кочкә таптым, атай.* Г.Ибраһимов

**Тыгыла бару** Торган саен ныграк тыгылу. *Ничаклы тыгыз булса да, әле һаман бүлмәләрдән шәкерт агыла, һаман берсен-берсе кысып, шул тыгыз тулган залга тыгыла баралар.* Г.Ибраһимов

**Тыгыла башлау** Тыгылу билгеләре күренү. *Халыкның күз алдында ук бозлар елганың як-ягына түгелгән тирес белән тарайган җиренә тыгыла башлады.* А.Алиш. *Тегесе артык узынып китеп дәүләт эшләренә дә тыгыла башлагач, аны юлдан алып ташлау ягын карый.* А.Хәсәнов

**Тыгыла төшү** Тагын да күбрәк тыгылу; бераз тыгылу. *Борыным тагын да тыгыла төште.* Сөембикә

**Тыгыла язу** Аз гына тыгылмый калу. *Көтмәгәнлектән ризыгы тыгыла яза.* Р.Гаязетдин. *Бу хәбәрне ишеткәч, бәрәңге белән тыгыла яздым.* Казан утлары

**Тыгылып алу** Бераз тыгылу; аз вакытка тыгылу. *Шушы егетләрнең --- төз адым белән атлап, хәрби антның һәр сүзен чатнатып һәм гаять җитдилек белән әйтүен тыңлап, үземнең дә бугазыма төер тыгылып алды бугай.* Мәдәни җомга

**Тыгылып бетү** Тәмам тыгылу. *Нәтиҗәсе мәгълүм: ком һәм чүп-чар белән тыгылып беткән, өлешчә җимерелгән инженерлык коммуникацияләре Казан урамнарында сулар җыелуга китерә башлады.* Шәһри Казан

**Тыгылып йөрү** Даими тыгылу; һәрвакыт, һәр җирдә тыгылу. *Бәлки, минем чынлап та кешеләр язмышына тыгылып йөрергә хакым юктыр?* Э.Яһудин. *Икенчедән, минемчә дин әһелләренә гыйлемле татар зыялылары кирәк түгел, үзләренең мохитләренә, эшләренә артыгын тыгылып йөрүләрен теләми сыман тоела.* Н.Алан

**Тыгылып калу** Тыгылган хәлгә килү. *Кино күрсәтү аппаратына лента тыгылып калганда экранда калтыранган бердәнбер кадр кебек, Хәлимнең хәтер лентасында ниндидер бер мөһим күренеш катып калды ---.* Г.Гыйльманов. *Тик җикеренү сүзләре бугазында тыгылып калгандай булды.* И.Сиражи

**Тыгылып китү** Кинәт тыгылу. *Хәер, Фәрит, картларның сүз сөрешләре ничек барганы белән дә кызыксынып тормастан, шунда ук тыгылып китәргә дә күп сорамый иде шул.* Ш.Алпар

**Тыгылып тору** Һәрвакыт тыгылу; хәзерге моментта тыгылган булу; даими тыгылу. *Монда әллә ни көләрлек нәрсә булмаса да, киресенчә, ачуланырга кирәк булса да, Барыйның да инде күңелендә тыгылып торган боз кисәге эреп юкка чыккандай булды.* Н.Фәттах. *Шул вакыт әллә ни зур булмаган бер боз агып килә дә тыгылып торган бозларга китереп бәрә.* Ф.Яруллин

**ТЫГЫЛЫШ** *и.* 1) Кысанлык, этеш-төртеш. *Гардероб янында кеше күп, тыгылыш.* Р.Батулла

2) Тыгылган урын; бөке. *Көймәдән көймәгә сикереп, тыгылышка килеп җиткәч кенә, тозакка эләккәнен аңлады.* Тарих эчендә ниләр бар? *Үзәк урамнардагы тыгылыш, бөкеләр башымнан бер минутка да чыкмый.* Шәһри Казан

**ТЫГЫЛЫШУ** *ф. урт. юн.* Бер урынга күпләп тыгылу, жыелу, өелешү. *Биек ишек тагын ачылды, һәм, тыгылышып, тагын теге егетләр керделәр.* М.Мәһдиев. *Елга борылышында тыгылышкан бозлар өстеннән синең сумкаңны табып кайттылар.* Ф.Яруллин

**ТЫГЫН** *с.* **1.** Кысан, кысрык, иркен түгел. *Алар иң кыен чакларда килеп йөрделәр, тыгын димәделәр, үзләре янына мине сыендырдылар.* Ф.Яруллин. *Адәм баласының асылы башка беркайда да түгел, нәкъ менә тыгын автобуста ныграк ачыладыр.* М.Кәбиров. *Халык күп, кая карама – тыгын, тынчу.* Р.Туфитуллова

**2.** *и. мәгъ. диал. к.* **тыгынчык**. *Тишеккә – тыгын, ертыкка – ямау.* Мәкаль

**ТЫГЫНДЫРУ** *ф. туп.* 1) Күп итеп, туйганчы ашату-эчертү. *Дөнья кадәр күчтәнәчләр биреп җиңгәләрен тыгындырдым.* Т.Гыйззәт. *--- чучка асрый хәзер татар, ипекәйне улагын тутырып тыгындыра, чүмәлә тиклем бишәр чучка асраучылар бар!* А.Гыйләҗев

2) Ришвәт бирү һ.б.ш. юл белән ризалату, канәгатьләндерү. *Мине – астагылар, мин өстәгеләрне тыгындырам, аның өчен ул суммаларны каяндыр алырга кирәк бит әле.* Р.Сәгъди

**Тыгындырып бетерү** Барысын да тыгындыру; нык тыгындыру. *Кара аны, кызлардан тыгындырып бетермә.* Т.Гыйззәт

**Тыгындырып яту** Озак вакыт дәвамында тыгындыру. *Нәрсәгә аларны Алчын бәк заманындагы кебек бушка тыгындырып ятарга.* Р.Сәгъди. *Әрәмтамак, үзеңнең тамагың тыгынганы җитмәгән, инде монда урам хәерчеләрен дә тыгындырып ятасыңмы?* Бу тормышта ниләр бар?

**ТЫГЫНЛЫК** *и.* Кысанлык, тыгызлык, урын тарлыгы. *Байлар әйтә, шундый мөхтәрәм кешене тыгынлыкта яшәтү гөнаһ, диләр.* М.Маликова. *Вәт, вәт, болай тыгынлык булгач, сиңа (ул үзе дә сизмәстән «син»гә күчте) уңайсыз түгелме соң?* А.Вергазов

**ТЫГЫНУ** *ф. туп.* 1) Өсте-өстенә ашау, күп итеп ашау. *Үләсен белсә дә, күп кеше рәхәтләнеп ашый: тыгыналар, комсызланалар.* Р.Батулла. *Безгә килеп тыгынып кына китә беләсез шул сез, рәхмәтегез шулдыр.* Г.Каюмов

2) *күч.* Байлык, акча һ.б.ш.ны ашауэчүгә, кәеф-сафа сөрүгә тоту. *Тыгыныгыз инде безнең акчага!* Г.Камал. *Эшләгәнеңне шайтан суы тыгынып бетерәсең!* Х.Камалов

**Тыгына башлау** Тыгынырга тотыну

**Тыгынып тору** Даими тыгыну; хәзер тыгыну

**Тыгынып яту** Озак вакыт тыгыну. *Үзләре монда җылы өйләрдә тыгынып яталар, безнең кебек ярлыларны сугышларга куып, ачтан тилмертәләр.* Т.Гази. *Ул оятсыз үзе дә Бәдретдин юнәткән ит, май белән тыгынып ята бит.* С.Сабиров

**ТЫГЫНЧЫК** *и. диал.* 1) Шешә авызын, мичкә тишеген яки башка шундый тишекне томалый торган нәрсә; бөке. *Тыгыз җиргә тыгынчык.* Мәкаль. *Син шушылай итеп өрелгән ат алгансың. Тыгынчыгы юлда төшкән*

*дә, шуңа күрә атың ябыга башлаган булырга кирәк.* Ш.Камал

2) *иск.* Морҗаны, төнлек тишегеН томалый торган киез, чүпрәк. *Төнлек тыгынчыгы. Морҗа тыгынчыгы*

**ТЫЕЛГАН** *с.* Файдаланырга, кулланырга, эшләргә ярамый торган; тыюлы. *Шту син, иптәш Вәлетдинов, кул белән чәчү – упшым да тыелган эш бит.* М.Мәһдиев. *Чөнки һәр заман өчен дә тыелган әйберләр бар, һәр илнең дә үз дәүләт сере бар.* Ф.Бәйрәмова

**ТЫЕЛГЫСЫЗ** *с.* **1.** Берни белән дә туктатып яки тоткарлап булмый торган. *Гөлшаһидә тыелгысыз бер ярсу белән Мансурның муеныннан кочып алып, иреннәреннән суырып үпте.* Г.Әпсәләмов. *Аның күзләре зур ачылып яктырган, аларда киек җәнлек күзендәге кебек сизгер ут кабынган, гәүдәсе турайган, киеренкеләнгән, әйтерсең лә каядыр сикерергә яки тыелгысыз омтылыш белән йөгерергә әзерләнгән иде.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Берни белән дә туктатып яки тоткарлап булмаслык рәвештә. *Кемнәрдер башлап җибәргән ташкын безне тыелгысыз алга илтә.* Ш.Галиев. – *Әти белән әни юк инде минем, – диде кыз, тыелгысыз аккан күз яшен сөртә-сөртә.* В.Нуруллин

**ТЫЕЛГЫСЫЗЛЫК** *и.* Тыелгысыз булу. *Тагын йөрәк үзенең бөтен тынгысызлыгы, йөгәнсезлеге, тыелгысызлыгы белән өстенлек алган.* Г.Әпсәләмов. *Алай да язларын йорт казлары сыман, каннарында ерак яшьлек тынгысызлыгы, тыелгысызлыгы бер уянып, уйнап ала.* Ш.Галиев

**ТЫЕЛДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тыелу**. *Аның да, үз-үзен белештерми, берәр усал адәм затыннан андый кызларны саклап калганы яки, киресенчә, үзе шундый адәм заты сыйфатына кереп, башкалардан тыелдыручы таләпләрне ишеткәне булгаламадымы?..* Ф.Яхин

**ТЫЕЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тыю**. *Читләр әйберсенә кагылу корсаклы хатынга да тыела!* М.Хуҗин. *Мөселман кешесенә зина кылучы белән никахка керү катгый рәвештә тыела.* И.Әмирхан

2) *кайт. юн. к.* **тыю**. *Арткарак калып төшә торган чаңгычы – соры костюмлы, аркасына ау мылтыгы аскан егет – тыелыбрак шуа.* Г.Әпсәләмов. *Мин инде болай ярамаганлыгын бик яхшы аңлыйм, шулай да берничек тә тыелып булмый.* Н.Фәттах. – *Мин сезне бередә дип белми идем, – диде ул, мөмкин кадәр тыелып ---.* Ф.Садриев

**Тыела башлау** Тыелырга тотыну; тыелганлыгы сизелү. *Машина уылдап әкренәя, тыела башлады.* Р.Батулла

**Тыела калу** *к.* **тыела төшү**. *Бераз тыела калып, Маһинур апаның гүзәл күз карашлары, зифа буе, кара чәч вә кашлары, күңел кылларын чиртә торган озын керфекләре – һәммәсе-һәммәсе күз алдыма килделәр.* Ф.Яхин

**Тыела төшү** Бераз тыелу; тагын да тыелу. – *Ә үзе! – диде Атилла бераз тыела төшеп.* М.Хәбибуллин. *Аннан нигәдер мал куучыларны мактаудан тыела төшеп, сүзне икенчегә борды.* Ф.Сафин

**Тыелып калу** Кинәт тыелу. *Күңеле тулды, тик үзен үзе кулга алды, тыелып калды.* З.Мәхмүди. *Ә егет куллaрына ирек бирми, тыелып кала бедә.* Ф.Яруллин. *Зал уртасына якынлашу белән, өстәл янындагы алыпларны күрү белән, алар көлүдән, сөйләшүдән тыелып калдылар.* Н.Фәттах

**Тыелып килү** Электән үк, эзлекле рәвештә, озак вакытлар дәвамында тыелу. *Күп гасырлар дәвамында тыелып килгән матбугаты мәйданга чыккан, һәм шагыйрь милләткә хокук таләп итә.* Н.Хисамов

**Тыелып тору** Билгеле вакытка тыелу. *Дөрес, люмпеннан чыгып, сату эшенә тотынган бәндәләр генә бернинди җинаятьтән дә тыелып тормыйлар иде.* М.Галиев. *Аның тавышы шундый сагышлы, шундый кызганыч чыга, мин, елап җибәрмичә, көчкә тыелып торам.* Р.Вәлиев

**ТЫЕЛУЧАН** *с.* Берәр эш эшләүдән, сүз әйтүдән үзен үзе тыя торган. *Сез безнең белән генә шундый тыелучанмы ул?* И.Гази

**ТЫЕНКЫ 1.** *с.* 1) Хис-тойгыларын, уйларын артык сиздерми торган, тыйнак, тыныч, басынкы, сабыр (кеше тур.). *Кире әйләнеп килгәндә, Лариса белән Әнвәр икесе дә бик тыенкы иделәр.* М.Маликова

2) Бар көченә чагылмаган, тыйнак, чамалы. *Тормыш корып җибәргән көннән башлап, Ләйлә белән Гайфулла арасында тыенкы мәхәббәт яшәп килде.* Ф.Яруллин. *Тавыш тыенкы, беркадәр моңсу булса да, ягымлы.* Х.Ширмән

**2.** *рәв. мәгъ.* Тыйнаклык, сабырлык белән, тыныч кына. *Урта бер җирдә кайчандыр тыенкы гына челтерәп торган фонтан булган.* М.Галиев. *Зәбидә нигәдер тыенкы гына, сүзгә кушылмый бара.* Н.Хәсәнов

**ТЫЕНКЫЛЫК** *и.* Тыенкы, сабыр булу сыйфаты. *Аның тавышындагы әрнүле тыенкылык чалымы Әнвәрнең күңелен тырнады, әмма яңадан шалтыратып сөйләшергә уңайсызланды.* Х.Камалов. *Ул олыларча бер тыенкылык белән минем кочагыма килеп сарылды.* Ф.Яруллин

**ТЫ́З-БЫЗ** *иярт. сөйл.* **1.** Бик күпләрнең әле бер, әле икенче якка берәр эш белән йөрүе, арлы-бирле килүе турында.

**2.** *рәв. мәгъ.* Әле бер, әле икенче якка, арлы-бирле килеп (хәрәкәт итү һ.б.ш. тур.). *Болак күпереннән тыз-быз үтеп торган трамвай, автомашина тавышлары, шәһәр гөрелтесе һаман тоныклана барды.* Н.Фәттах. *Хөкүмәткә дә эшли, тыз-быз өендә дә чаба.* Р.Габделхакова

**ТЫЗ-БЫ́З КИЛҮ** *ф.* Ашыгудан яки каушаудан ыгы-зыгы килү, ыгы-зыгы килеп йөрену. *Анда береннән-бере чибәрләр: Нәсимә белән Зөлфия, Зөмәррә белән Әлфинур, Мөфидә белән Рушания, Мәрьям белән Гүзәл каракаршы утыралар, Гөлшатлары тыз-быз килә.* К.Миңлебаев. *Хәзрәт, чапан чабуларын җилфердәтеп, һаман хәрәкәтләнә, тыз-быз килә.* М.Хәсәнов

**ТЫЗГЫЛДА́У** *ф. сөйл.* Берәр нәрсәдән риза булмавы турында ачуланып сөйләп тору; канәгатьсезлек белдерү. *Тызгылдама әле юкка!*

**Тызгылдый бирү** Бернигә дә карамый тызгылдау; һаман тызгылдау

**ТЫЗДЫ́Й-БЫЗДЫЙ** *рәв. сөйл. к.* **тыз-быз**

**ТЫЗДЫ́Й-БЫЗДЫЙ КИЛҮ** *ф. к.* **тыз-быз килү**. *Халык тыздый-быздый килеп йөри.* Чаян

**ТЫЗЫЛДА́У** *ф.* 1) Бызылдау, тонык кына ыжылдаган тавыш чыгару. *Тызылдап әйләнгән телефон өстәлдән килеп төшәм дигәндә генә, ватыла күрмәсен тагы дип эләктереп алды.* Ватаным Татарстан

2) Ишетелер-ишетелмәс яки аңлап булмаслык итеп бер көйгә сөйләнү. *Һаман тызылдый инде ул шулай*

**Тызылдап алу** Аз гына тызылдау. *Чебен тызылдап алды да тынды*

**Тызылдап йөрү** Озак вакыт дәвамында тызылдау. *Сәлим тызылдап йөрде-йөрде дә, игътибар итүче булмагач, сүрелде тагын.* И.Нуруллин

**Тызылдап кую** Бер тапкыр гына тызылдау

**Тызылдап тору** Сөйләү моментында тызылдау. *Әниең гел тызылдап торамы?* Казан утлары

**Тызылдый бирү** Бернигә дә карамый тызылдау

**ТЫЙБ** *и. гар. кит.* Медицина. *Хәшәрәт микробларны да эчәргә өйрәтсәк, спиртның тыйб эшендә кирәге калмас.* З.Мансуров. *Тыйб гыйлеменең терелтү мөмкинлеге булса, арабызга кайткан ерак бабаларыбыз безнең ни хакта сөйләшкәнебезне аңлап та бетермәс иде.* Р.Рахман

**ТЫЙББИ** *с. гар. кит.* Медицинага бәйләнешле, медик. *Ышанмый ни эшлисең, ул бит тыйбби мәктәп бетергән.* Г.Ибраһимов. *Китапханәдә дистәдән артык тыйбби эчтәлекле кулъязмалар бар.* Р.Мәрдәнов

**ТЫЙЛЫГУ** *ф. диал.* 1) Берәр эшне эшләүдән үз-үзен тыю; туктау; кире уйлау. *Ниһаять, карчыкның сүз капчыгы бушабрак калды бугай, әллә карты әрепләшмәгәнгә, шул төштә тыйлыкты.* Ә.Баян. *Чөнки Әлтафиның рәвешен күргән кызлар, үзләре дә сизмәстән, нәкъ ул булып чүгәләгәннәр һәм, эчләрен тотып, тыйлыга алмыйча көләләр иде.* М.Мәһдиев

2) Кимү, бераз тукталу, әкренәю, басылу (авырту яки җил-яңгыр тур.). *Яңгыр тыйлыккан арада барып кайтсак була инде кибеткә.* Казан утлары

**Тыйлыга бару** Торган саен күбрәк тыйлыгу. *Җил тыйлыга бара*

**Тыйлыга башлау** Тыйлыгу билгеләре сизелү

**Тыйлыга төшү** Бераз тыйлыгу. *Аннары бераз тыйлыга төште дә: – Яп әле ишекне дә кил монда!* В.Нуруллин

**Тыйлыгып калу** Ниндидер бер вакыйгадан, хәлдән соң тыйлыгу. *Тагын нидер өстәмәкче иде, тыйлыгып калды.* Ә.Баян. *Бу сүз вакытында усал әйтелгән иде: Исламнур да, Ярмөхәммәт тә тыйлыгып кала алмады.* Р.Батулла

**Тыйлыгып тору** Һәрвакыт тыйлыгу, даими тыйлыгу; билгеле вакытка тыйлыгу. *Сабырлык галәмәте – тыйлыгып тору.* Ә.Баян

**ТЫЙЛЫК** *и. диал.* Киртә, комачау, тоткарлык; берәр эшне яки хәрәкәтне тоткарлаган, туктаткан нәрсә. *Һәр эшеңә тыйлык салырга теләүче көнчеләр күп булыр ул, игътибар итмәскә өйрән, сеңлем.* Кызыл таң

**ТЫЙЛЫКСЫЗ** *с. диал.* 1) Туктату мөмкинлеге булмаган, тыелгысыз. *Тыйлыксыз хәрәкәт. Тыйлыксыз сүз*

2) Боелыгын тота алмаучан. *Тыйлыксыз бала*

3) Тотнаксыз. *Тыйлыксыз кеше*

**ТЫЙЛЫКСЫЗЛАНУ** *ф. диал.* 1) Үзен теге яки бу эштән тыя, тота алмау, тотнаксызлык күрсәтү. *Тыйлыксызланма, үз илеңдә түгел ---.* Кызыл таң

2) Боелыгын тота алмас булу; сидекне тота алмый башлау

**ТЫЙЛЫКТЫРУ** *ф. диал.* 1) Теге яки бу эшне эшләүдән тыю, тотып калу. *«Аның холкы яман, борыны озын» дип сине сөюдән тыйлыктырамыни, ул тота да өлешеңә тигән көмешеңә гашыйк иттерә.* Н.Гыйматдинова. *Нидер тоткарлаган, кемдер тыйлыктырган.* Истәлекләр

2) Әкренәйтү, тоткарлау, туктату. *Эшне тыйлыктыру*

**Тыйлыктырып тору** Билгеле вакытка тыйлыктыру. *Ташлап качар чакларда, аны әнисеннән килгән хатлар гына тыйлыктырып торды.* А.Гыйләҗев

**ТЫЙНАК** *с.* **1.** 1) Үзен мактарга, күрсәтергә яратмый торган, сабыр, басынкы. *Беренчесе – үтә дә беркатлы, бар нәрсәгә дә тиз ышанучан, шатлыктан күккә сикерми, кайгы-хәсрәткә тиз генә бөгелеп төшми торган сабыр, тыйнак зат.* Г.Галиев. *Илдар Юзеев тыйнак шагыйрь булу өстенә, кеше сүзенә колак сала белә.* Ф.Яруллин

2) Әдәпле, тотнаклы, басынкы, тәрбияле, әхлаклы. *Тыштан тыйнак, сабыр, әдәпле, кешегә авыр сүз дә әйтми торган Зәкиҗан агай характерын күрсәтте: инанган хыяллары өчен үләргә әзер фаталист икәнлеген раслады.* Т.Галиуллин. *Юк, Мәүлия андый түгел, тыйнак хатын ул.* Аманулла

3) *күч.* Артык бай булмаган, күзгә бәрелеп тормаган, гади. *Кичен ярлы өйдә ярлы гына, тыйнак кына бәйрәм булды.* Н.Фәттах. *Һәммәсенә түзеп, сабыр гына Кичергәннәр тыйнак авыллар.* Л.Шагыйрьҗан

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тыенкы, тотнаклы рәвештә; әдәпле; үзен күрсәтергә тырышмыйча. *Алмыш хан, мактау сүзләренә күңеле булып, тыйнак кына тамак кырып куйды.* Н.Фәттах. *Бу мөхтәрәм зат һәркайда, һәркайчан үзен намуслы, тыйнак тотты.* Х.Миңнегулов

2) Әдәп, тәрбия, әхлак кагыйдәләрен бозмыйча. *Бу, әлбәттә, бик әдәпле, бик тыйнак сөйләшү иде, әмма ләкин иң чынын, иң кирәген сөйләшү түгел иде, чөнки бу минутта аларның күңелләрендә бөтенләй икенче уй, икенче хисләр иде.* Ә.Еники

3) *күч.* Гади итеп; бай һәм мул итмичә. *Әмма балалары бик тыйнак кайтып төштеләр. Машинасыз-нисез.* Ф.Яруллин. *Моннан утыз еллар элек авыл халкы бик тыйнак яши иде, ә бер ир шул вакытта кинәт кенә нык баеп китте: болын кадәр йорт салды, машина алды.* Г.Хуҗиева

**3.** *и. мәгъ.* Әдәпле, сабыр холыклы кеше. *Тыйнакның кулы эшләр, мактанчыкның теле эшләр.* Мәкаль. *Тыйнакның тыны юк, күкрәп чыкмас бер дә.* Ю.Сафиуллин

**ТЫЙНАКЛАНУ** *ф.* 1) Тыйнакка әйләнү, тыйнак булып китү, үзен тыйнак тота башлау. *Сары бөдрә чәчләрен пилоткасы эченә яшерә-яшерә, Стариков тагын сүзгә кушылды: – Иптәш парторг алдында тыйнакланма әле, Газинур, Александр Матросов турындагы беседаңны бөтен кеше ошатты.*

Г.Әпсәләмов. *Тыйнаклана отыры алар да.* С.Әхмәтҗанова

2) Тыйнак булып кылану, тыйнак булып күренергә тырышу. *Тыйнакланып, оялып тора торган чак түгел.* Ә.Еники. *– Синекенә җитми инде, – диде Гөлнара, тыйнакланып.* Ф.Яруллин

**Тыйнаклана бару** Торган саен, тагын да тыйнаклану. *Фестиваль елданел җиселе һәм исеме таләпләренә туры килгән рәвештә тыйнаклана, тотнаклана бара.* Мәдәни җомга

**Тыйнаклана башлау** Тыйнакланырга тотыну

**Тыйнаклана төшү** Бераз тыйнаклану; тагын да ныграк тыйнаклану. *Бу тормышта үзеңнең кечкенә генә урын алып торганыңа төшенгәндәй буласың, тыйнаклана төшәсең икән.* М.Хәсәнов

**Тыйнакланып бетү** Тәмам тыйнаклану. *Бөтенләй яхшырып, тәртипләнеп, тыйнакланып бетәрмен дә сәхнәдән китәрмен дип уйлыйм.* Тамаша

**Тыйнакланып калу** Берәр тәэсирдән соң тыйнакка әйләнү. *Башка вакытта кызлар яныннан узып киткәндә дә бер шаян сүз әйтмичә түзә алмаган егетләр, аны күргәч, тыйнакланып калдылар.* Л.Ихсанова. *Башка һөнәр ияләренең истәлеген мәңгеләштерү өчен җан атып һәм кан түгеп йөргән журналист халкы, мәсьәлә үз остазларына кагылганда, ни сәбәпледер юашланып һәм тыйнакланып кала.* Ватаным Татарстан

**Тыйнакланып китү** Соңгы араларда, күзгә күренеп, сизелерлек тыйнаклану. *– Язган булса, – диде ханым, басылып, тыйнакланып китеп.* Т.Галиуллин

**Тыйнакланып тору** Күпмедер вакытка тыйнаклану. *Кияү күрмәгән кызлардай тыйнакланып тору кирәкмәстер, мондый эзләнү һәм тарихи ачышларны теләсә кайсы матбага коллективы ерып чыга алмый, ул – фәкать «Мәйдан» журналы егетләренең генә кулыннан килгән хезмәт!* В.Имамов

**ТЫЙНАКЛЫ** *с. ялг. к.* **тыйнак**. *Дөрес, әдәпле вә тыйнаклы атабыз Адәм, оят саклап, янәдән 300 ел буена анабыз Хавага якын килми әле.* Г.Гобәй

**ТЫЙНАКЛЫК** *и.* Тыйнак булу сыйфаты. *Тыйнаклык, ниндидер бер уңайсызлану, үзе әйткәнчә, «татарлык» хас аңа.* Р.Миңнуллин. *– Нәрсәсенә рәхмәт инде аның, – дигән булды Вәгыйзь, тыйнаклык күрсәтеп.* Н.Фәттах

**ТЫЙНАКСЫЗ** *с.* Тыйнаклык сакламый, тыйнаклык күрсәтми торган; әдәпсез; тыела белми торган. *[Шәйхезаман:] Бу нинди тыйнаксыз балалар булды соң? Ялгыз калдылармы, талашырга керешәләр.* Т.Гыйззәт. *Моңарчы егет-җилән арасында Хәтирәгә карата үзенә бер төрле дорфа, тыйнаксыз мөнәсәбәт яши иде.* М.Галәү

**ТЫЙНАКСЫЗЛАНУ** *ф.* Тыйнаклык сакламау, тыйнаксызлык күрсәтү, әдәпсезләнү. *Әлегә тикле азмы-күпме әдәп саклаган кавалерым аулакта тыйнаксызланырга, шаярган булып, кулына ирек бирергә, капшанырга тотынды.* С.Сабиров. *Әнә табигать тә үзенең, тыйнаксызланып, кызның сылу тәненә кагылуына оялды бугай, яңгыр ничек кисәк кенә башланып киткән булса, шулай кинәт кенә туктады да.* И.Сираҗи

**ТЫЙНАКСЫЗЛЫК** *и.* 1) Тыйнаксыз булу, мактанырга ярату, күзгә ташланып тору үзлеге. *Тыйнаксызлык саналмаса, ул поэмамны иҗатымдагы иң әһәмиятле әсәрем дип исәплим.* Н.Нәҗми. *Тыйнаксызлык булып аңлашылмасын: язучылар, шагыйрьләр – халык тормышын тирәнтен белүчеләр.* Р.Миңнуллин

2) Әдәпсезлек, тәрбиясезлек, гадәтсезлек. *Чәчләрен никадәр тыйнаклык белән татарчалатып турыдан ачса, күкрәк уемын шулкадәр тыйнаксызлык белән тышка чыгарып, эре чәчәкле халат кигән хуҗабикә чыгышы белән Буа кызы, теш табибәсе булып чыкты.* А.Хәлим

**ТЫК** *иярт.* Берәр каты нәрсәгә каты яки тыгыз әйбер белән сукканда, төшергәндә чыккан бераз саңгырау тавышны белдерә. *Җырлы вагон алга тәгәри, вагон тәгәрмәчләре, туган якны якынайтып, тык та тык килеп әйләнәләр дә әйләнәләр.* Г.Галиев. *Ә сәгать өзлексез тык та тык, тык та тык.* Г.Хөсәенов

**ТЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Шундый аваз чыгару. *Тык итеп идәнгә уенчык килеп төшүгә, бала кычкырып елап җибәрде.* Казан утлары

2) Кизәнмичә сугу

**ТЫККЫЧ** *и. диал.* Бөке. *Шешә авызындагы тыккычны җәһәт кенә алды да икесенә дә тип-тигез итеп коньяк салды [Газиз].* И.Нуруллин

**ТЫКРЫК** *и.* Гадәттә ике параллель урамны тоташтыра торган кечкенә тар урам. *Ә менә алардан бер тыкрык аша гына яшәүче Гаяз абый үз кызлары өчен ни генә ясамады.* Ф.Яруллин. *Алар шулай тарткалашып торганда сизми дә калдылар, тыкрык башына тузанлы йөк машинасы килеп туктады.* М.Маликова

**ТЫ́К-ТЫК** *иярт.* Агачка, ташка һ.б.ш. каты әйбергә берничә тапкыр җиңелчә генә бәргәндә чыга торган өзек-өзек саңгырау тавышны белдерә. *Тып-тып, тык-тык, леп-леп. Алтмыш секундта алмагачтан алтмыш алма өзелеп төште.* Татарстан яшьләре

**ТЫ́К-ТЫК ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару, тыкылдау. *Сандалиларыбыз такыр юлдан тык-тык итеп кайта.* Л.Лерон. *Тык-тык итеп җырлап килә [ул].* И.Салахов

**ТЫ́К-ТЫК КИЛҮ** *ф. к.* **тык-тык итү**. *Ул таягы белән тык-тык килеп арлы-бирле йөри, үзе, якты дөньяны беренче мәртәбә күргәндәй гаҗәпләнеп, һаман бер үк сүзләрне кабатлый ---.* Р.Вәлиев

**ТЫКШЫНУ** *ф. сөйл.* 1) Бик кысан урынга керү, кысылу. *Шәһәр халкының бер-ике адым җиргә дә җәяү барасы килмичә, трамвай белән троллейбусында тыкшынырга ияләнеп бетүе?* Ә.Сафиуллин

2) Кая да булса әдәпсез яки оятсыз рәвештә керү, үтү, үтергә, керергә тырышу. *– Кая тыкшынасың, ары кит! – дип кычкырды би үзенең углына.* Н.Фәттах. *Ни кызганыч, андый бәхеткә күбрәк лаф орып йөрүчеләр, милләтпәрвәр кыяфәтенә кергән эшлексезләр, дан-дәрәҗә яратучы, ерып-ертып алгы рәтләргә тыкшынучылар ия.* Р.Миңнуллин

3) Белер-белмәс башка кешеләрнең эшенә, тормышына катнашу; тыгылу,

кысылу. *Һәркайсыбызның үз үткәне, анда теләсә кемнең тыкшынырга хакы юк.* М.Хәсәнов. *Утыз ел буе каенана белән яшәүче Камилә тормышына тыкшынып маташалар!* К.Тимбикова

4) Үти алмаслык, көче җитмәслек эшкә керешү. *Югары белеме дә булмаган кешенең директор эшенә тыкшынуын ничек аңлатырга?* Р.Вәлиева

**Тыкшына бару** Тагын да күбрәк тыкшыну. *Теге эшлексезләр моны сизәләр һәм шул көннең өлешенә тыкшына баралар иде.* М.Мәһдиев

**Тыкшына башлау** Тыкшынырга керешү. *Мафия артык баеса, симергән эт кебек, хуҗаларына ташлана, икътисади, сәяси эшләргә тыкшына башлый.* Т.Галиуллин. *Бик тыкшына башласалар, җибәр син аларны.* М.Маликова

**Тыкшынып йөрү** Озак вакыт дәвамында тыкшыну; даими тыкшыну. *Анда мин карьера өчен тырмашып, тыкшынып йөрүче адәми зат булып кына күренәм.* Т.Миңнуллин. *Минем хуҗалыкка тыкшынып йөргәнче, отрядыңда тәртип урнаштырыр идең.* Р.Вәлиев

**ТЫКШЫНУЧАН** *с.* Тыкшынырга яратучан. *Тыкшынучан кеше*

**ТЫКШЫНУЧАНЛЫК** *и. к.* **тыкшынучылык**

**ТЫКШЫНУЧЫЛЫК** *и.* Тыкшынырга ярату, тыкшыну гадәте. *Тыкшынучылык безнең милләткә генә хас түгел инде ул.* И.Газиев

**ТЫКЫЛДАТУ** *ф.* Таш, агач һ.б.ш. каты нәрсәләргә сугып, бәреп тык-тык иткән тавышлар чыгару. *Шәүкәтне генә көткәндәй, калганнар да чүкечләрен тыкылдатырга керештеләр.* Н.Хәсәнов. --- *Мансур агай исән кулы белән стенаны тукмап-тукмап көлә, Бүресуккан олатай таягын тыкылдата, Хәйрулла агай шап та шоп ботын чаба.* Г.Якупова

**Тыкылдата башлау** Тыкылдатырга керешү. *Ул да түгел, автоматлар тагын тыкылдата башлый, һәм Коненконың күңеле тагын тынычланып китә: «Димәк, әле исәннәр...»* И.Гази

**Тыкылдата бирү** Бернигә карамыйча тыкылдату. *Баш редактор каләме белән өстәлгә тыкылдата бирде.* Казан утлары

**Тыкылдатып алу** Бераз гына тыкылдату; кыска вакыт тыкылдату. *Бабай, гадәттәгечә, таягы белән берничә тапкыр тыкылдатып алды.* М.Мәһдиев

**Тыкылдатып йөрү** Гел тыкылдату. *Һаман тыкылдатып йөрүен генә белә ул ---.* Казан утлары

**Тыкылдатып кую** Бер тапкыр тыкылдату. *Мансур, мин риза дигәнне белдереп, кулындагы чүкеч белән тыкылдатып куйды.* А.Галиева

**Тыкылдатып тору** Озак вакыт дәвамында тыкылдату; даими тыкылдату

**Тыкылдатып утыру** *к.* **тыкылдатып тору**. *Аннары ул икенче бер бинага керде һәм анда немец телеграфистының аппарат янында, бармак басып, нидер тыкылдатып утыруын күрде.* Г.Кутуй

**ТЫКЫЛДА́У** *ф.* 1) Тык-тык иткән тавыш чыгару. *Якындагы тимер юлдан, күңелле тыкылдап, поездлар үтеп китә.* М.Маликова. *Ә инде сарыга буялган тупса янында ап-ак ирләр туфлие күргәч, йөрәге мотоцикл моторыннан әшәкерәк тыкылдап тибәргә тотынды.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Туктаусыз бик күп сөйләү; әһәмиятсез, мәгънәсез, юк-бар нәрсәләр сөйләү, туктаусыз такылдау. *Аннары кайберәүләрнең пыш-пыш итеп тыкылдап йөрүләре дә тәэсир иткәләде.* Г.Кутуй

**Тыкылдап йөрү** Гел тыкылдау. *Аннары кайберәүләрнең пыш-пыш итеп тыкылдап йөрүләре дә тәэсир иткәләде.* Г.Кутуй. *Шулай берүзем тыкылдап йөрүем өчен, мине хәзер балачагалар гына түгел, кайбер зурлар да тилегә санnetwork.* Ф.Яруллин

**Тыкылдап ташлау** Уйламыйча, кызулык белән тыкылдау. *Әлләниләр тыкылдап ташладым бугай.* Г.Каюмов

**Тыкылдап тору** Сөйләү моментында тыкылдау; бертуктамый тыкылдау; һәрвакыт тыкылдау. *Шундый инде ул минем хатын, гел тыкылдап тора.* Безнең гәҗит

**Тыкылдый башлау** Тыкылдарга тотыну. *Иртәнге тынлыкны ярып, пулемёт тыкылдый башлады.* Р.Мостафин. – *Гаилә үрнәге күрсәтергә куша безгә китап, – дип, кәефе күтәрелгән Зөлфия рәхәтләнеп тыкылдый башлады.* Т.Галиуллин

**Тыкылдый бирү** Тыкылдавын дәвам итү; бернигә карамыйча тыкылдау. *Немец, күзләрен акайтып, як-ягына карады, бармакларын аппараттан алган иде, аппарат, колакка ят ишетелгән ноктлар һәм сызыклар ясап, тек, тек, тик, тик тыкылдый бирде.* Г.Кутуй. *Поезд тәгәрмәчләре ашыга-ашыга тыкылдый бирде.* М.Вәлиев

**ТЫКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн.* 1) Күп кеше мәгънәсезгә сөйләшеп утыру; юк-бар, әһәмиятсез нәрсәләр турында сөйләшү. *Синең белән тыкылдашып, көн үткәне дә сизелмәгән бит, әй.* Р.Вәлиев

2) Берничә кешенең яки әйбернең тыкылдаган тавышлар чыгаруы; күмәкләшеп тыкылдау. *Ул вагон тәгәрмәчләренең бер уңайга тыкылдашуын тыңлап, купеда рәхәт йокымсырап утыра.* Ватаным Татарстан

**ТЫКЫЛТ** *иярт.* Җиңел әйбер берәр каты өслеккә бәрелгәндә, төшкәндә, бер мәртәбә ишетелгән тавышны белдерә

**ТЫКЫР** *и. тар.* Киндердән тегелгән һәм озынлыгы тезгә кадәр җитә торган ирләр күлмәге

**ТЫКЫРДАТУ** *ф.* 1) Тыкыр-тыкыр иткән тавыш чыгару. *[Камырны] тагын күпмедер тыкырдатып туглый да, чүлмәкне мич алдына – җылыга куя.* Г.Бәширов. *Мин, юа торган тустаганымны тыкырдатудан туктап, җырның ахырын көтәм.* Ватаным Татарстан

2) *күч. сөйл.* Берәр нәрсә турында кат-кат сорау, әйтү, сорашу. *Алар Кардәшевтән шундый кызыклы авыл турында тыкырдатып сораша башладылар.* Х.Камалов

3) Кыстау, ирексезләү. *Бар, бар, дип, бабай тыкырдата.* Х.Камалов. *Хәер, җәмәгатьчелек эшенә катнашырга атлыгып та тормый иде, поссоветка да Фәрхия тыкырдатканга гына барган иде.* М.Хуҗин

4) *күч.* Ашыктыру. *Ә мин килүгә эш коралы алырга чабам, корал таратучыны тыкырдатам: «Кая минем чүкеч?»* А.Гыйләҗев. *Шундый сөйләшүләрдән соң ул авылда музыка мәктәбе*

*төзи башлау идеясен тыкырдатырга тотынды.* З.Зәйнуллин

5) *күч.* Бик нык ачулану, сүгү. *Бу вакытта Иван Мөхәммәтович телефон аша колхоз рәисләрен тыкырдата иде.* Х.Камалов. *Житәкченең тыкырдатуына түзәр чарам калмады, китәм мин бу эштән.* Казан утлары

**Тыкырдата башлау** Тыкырдатырга тотыну. *Бүген дә «Газель»гә кереп утырулары булды, кондуктор билет алырга тыкырдата башлады.* В.Нуриев

**Тыкырдатып алу** Аз гына тыкырдату. *Ул бармаклары белән өстәлгә тыкырдатып алды.* З.Зәйнуллин

**Тыкырдатып ташлау** Тиз генә тыкырдату. *Хәзер «бабаң» да «бабалары», имеш. Хурланмаслыкмыни? Вәт шуңа тыкырдатып ташладым Марзия апаңны.* Б.Камалов

**Тыкырдатып тору** Даими тыкырдату; хәзерге вакытта тыкырдату. *Казаннан да шуны тыкырдатып торганнарын син яхшы беләсең.* Ф.Садриев

**ТЫКЫРДА́У** *ф.* Тыкыр-тыкыр иткән ритмлы тавыш чыгару. *Нинди тавыш дисәм, юлда арба тыкырдый икән.* Г.Мөхәммәтшин. --- *тактага тамчыларның тыкырдап бәрелүе, машинаның тонык гүләве бергә кушылып, ниндидер ят, әмма күңелгә ятышлы көй хасил итә.* Өмет

**ТЫКЫ́Р-ТЫКЫР** *иярт.* Тимер, агач һ.б.ш. каты әйберләр бер-берләренә тиеп ышкылу, кырылудан чыккан тавышны белдерә

**ТЫКЫ́-ТЫКЫ** *иярт.* **1.** *к.* **тык-тык**. *Бер колагымда аның тавышы чыңлый, икенчесендә поезд тәгәрмәчләре тукылдый: тыкы-тыкы, тыкы-тыкы.* Р.Габделхакова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шундый тавышлар чыгарып. *Поезд күптән кузгалган, тыкы-тыкы бара да бара.* Р.Батулла

2) Берөзлексез, бик кызу, ашыгып (сөйләү тур.). *Эшләргә кирәк, тыкы-тыкы тыкылдап кына эш бармас.* Г.Галиев

**ТЫКЫ́-ТЫКЫ ИТҮ** *ф.* 1) Тык-тык иткән тавыш чыгарып тору, тыкылдау. *– Тыкы-тыкы итеп бик озак барыр әле бу поезд, йоклап алырга кирәк, – диде дә Гали, сузылып ятты.* Казан утлары

2) Бертуктаусыз, берөзлексез сөйләү. *Тыкы-тыкы сөйләп торырга кеше бар ул, хәлеңне аңлар кеше генә юк.* Р.Вәлиев

**ТЫКЫ́-ТЫКЫ КИЛҮ** *ф. к.* **тыкы-тыкы итү**. *Тик бу хәләте озакка сузылмады, ул, гадәтенчә, автоматтан сиптергәндәй, тыкы-тыкы килә башлады.* Казан утлары. *Дәресләрдән соң калып, берүзе аудиториядә тыкы-тыкы килеп, бер бармактан өч бармакка күчеп, аннары бөтен бармаклары белән дә уйнарга өйрәнә.* Кәеф ничек?

**ТЫЛ** *и. рус* 1) Сугыш алып бара торган илнең фронт сызыгы артындагы территориясе. *Башта мин сезгә сугыш вакытында безнең тыл халкы нәрсә ашаганны сөйлим.* М.Мәһдиев. *Тыл дигәннәре дә фронттан ким булмаган.* Ф.Баттал

2) Теге яки бу гаскәри берләшмә урнашкан, позиция тоткан урын артындагы территория. *Кремневның полкы әле җирле сугышлар алып барды, әле оборонада утырды, әле аны тылга ялга чыгардылар.* Г.Әпсәләмов. *Караңгы төшкәндәрәк искә килдем, безнең тыл дигән җирдә дә немецлар иде.* Х.Камалов

3) Хәрәкәттәге армия артында урнашкан һәм аны сугыш алып барыр өчен бөтен кирәк-яраклар белән тәэмин итә торган ярдәмче гаскәри частьлар, интендант берләшмәләр җыелмасы. *Шуның яратуыннан файдалан, тыл армиясенә күч, Алексей.* Х.Камалов. *Кирәк булса, Югары генералитеттан кешеләр һәм тыл начальнигы чакырыла.* З.Зәйнуллин

4) *күч.* Терәк, нигез; рухи байлык, кыйммәтләр тупланмасы. *– Белмим тагын, – дидем мин салкын гына. – Ләкин сиңа тыл булыр өчен генә иргә чыгуны аңламыйм мин.* Ә.Еники. *Ярый ла синең тыл нык иде.* М.Мәһдиев

◊ **Тылга бәрү** *к.* **тылга керү**. *Без киткәнне көтеп кенә торганнар диярсең, шул көнне үк тылга бәрделәр.* Казан утлары. **Тылга керү** Дошманның төп көчләрен әйләнеп үтеп, арттан һөҗүм итү. *Иогансонга да, Лангега да русларның нинди конкрет максат белән тылга керүләре билгеле түгел иде.* Г.Әпсәләмов. **Тылга төшү** *к.* **тылга керү**. *Бер кырыйдагы ике-өч чакрымлы тирән чокырдан --- килеп, безнекеләрнең киткәнен сагалап торган һәм шунда ук тылга төшкән.* Х.Камалов. **Тыл күсесе** *тирг., кимс.* Сугыш вакытында төрле юллар белән тылда калып, тыныч, рәхәт яшәүче кеше турында. *Ә ул тыл күсесе берни белми бит, ватанчы булып кылана гына, дидем.* Х.Камалов. *Дилбегә тыл күселәре кулында.* М.Әмирханов

**ТЫЛАКЫ́Й** *с. диал.* 1) Җилбәзәк. *Тылакый кыз*

2) Күп сөйләүчән, авызында сүз тормый торган; лыкылдык. *Мондый тылакый хатын-кыз белән ничек яшәрсең икән?!* Сөембикә

**ТЫЛАКЫЙЛАНУ** *ф. диал.* Күп сөйләнү; теленә ни килә, шуны сөйләү; җилбәзәкләнү. *– Яра-тыр-мын! – диде [Зөлхәбирә]. Уйнап әйтте, тылакыйланып әйтте.* Г.Ахунов

**ТЫЛАКЫЙЛЫК** *и. диал.* Тылакый булу. *Мин үзем тудырган хыялыма канәгать булып, шаян-тылакыйлыгым ташып чыгып, сикергәләп, атынгалап йөри башладым.* Гөлшәһидә

**ТЫЛКУ** *ф. диал.* 1) Тел белән әвәләү, йомшату

2) *күч.* Бер үк нәрсәне кат-кат әйтү, бер үк нәрсә турында кат-кат сөйләү; талку. *Әнә гәзите булсын, телевизоры – коммунизмга күп калмады дип, көне-төне тылкыйлар.* Д.Булатова. *Галимнәр, әлбәттә, Кояшта аңлашылмаган галәмәтләр булып ятуы турында үз фаразларын тылкый.* Кызыл таң

**ТЫЛКЫШ** *с. диал.* **1.** Тар, кысан, кысрык. *Тылкыш бүлмә*

**2.** *и. мәгъ.* Этеш-төртеш. *Урамдагы тылкыш*

**ТЫЛКЫШЛЫК** *и. диал.* Тыгызлыктан этеш-төртеш. *[Галимә:] Тылкышлыкны яратмыйм шул мин, үзең генә бар инде бу юлы.* Г.Галиев

**ТЫЛКЫШУ** *ф. диал. к.* **тыкшыну**. *«Җәллим», – диде Халисә, аны-моны уйламыйча. «Җәлләсәң, кочаклап ят, минем эшкә тылкышма!»* А.Гыйләҗев. *Ул да һич тынгы бирми, бер казандагы икенче тәкә башы кебек, гел тылкыша, үзенекен итмәкче була.* Истәлекләр

**ТЫЛМАЧ** *и.* Тәрҗемәче; телдән сөйләнгәнне тәрҗемә итүче. *Профессор боларны җыеп китап чыгарачагын тылмач аркылы сөйләде.* М.Мәһдиев. *Шуны сизгән тылмач, күзләремә ягымлы карап, саф татарча сорый.* Ф.Баттал

**ТЫЛМАЧЛА́У** *ф.* 1) Телдән тәрҗемә итү. *Тылмачлый алырлык кешеләр дә юк иде әле ул вакытта, алман телен үзебезгә өйрәнергә туры килде.* Р.Вәлиев

2) Катлаулы нәрсәне аңлату, аңлаешлы, гади тел белән сөйләп чыгу. *[Фәрхетдин] мәкаләне укып чыкты да аны Хөсәен аңлаткан рәвештә [крестьяннарга] тылмачларга кереште.* А.Расих

**ТЫЛМАЧЛЫК** *и.* Тылмач булу, тәрҗемәче эше. *Комендатурада тылмачлык итәм.* Т.Гыйззәт. *Әлеге татарлар арасында атчабарлар, тылмачлык йомышлары атадан балага күчкән.* М.Гайнетдин. *Монысы – тегесенә, тегесе Сакалбайга тылмачлык кылгач, Сакалбай: – Фу! – диде.* Ф.Баттал

**ТЫЛСЫМ** *и. гар.* **1.** 1) Берәр эшне башкаруда сихерле, серле алым; сихер. *Тылсым белән тартып китерер иде Наилә, тылсымы юк!* А.Гыйләҗев. *Чәйне ул, изге эш башкаручы фәрештәдәй тәфсилләп, бер касәдән икенчесенә авыштыра-авыштыра, ниндидер тылсым догалары укыгандай сөйләнә-сөйләнә пешерде.* Р.Батулла

2) Сер; аңлап, төшенеп булмаслык сыйфат, як. *Телнең бөеклеге, байлыгы, үлемсезлеге, бердәнберлеге, көч-кодрәте, тылсымы турында абстракт фәлсәфә, рәхәт оета торган вәгазьләр чоры үтте.* Р.Фәйзуллин. *Музыка тылсымы һәм спектакльдәге вакыйгалар бөтен күңел халәтен үзе белән әллә кайларга йөздереп алып китә.* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ.* Тылсымлы, сихри. *Сызылып төшкән нәзек тылсым кашка Ай нурлары явып сырышкан.* Ш.Бабич

**ТЫЛСЫМЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тылсымлау**. *Зәйтүнә үзе күргән нәрсәгә ышанырга да, ышанмаска да белмәде һәм шул ук вакытта һаман зурая, һаман ачыклана барган якты утлардан күзен ала алмыйча, тылсымланган, сихерләнгән шикелле тәрәзәгә капланып тик торды.* Н.Фәттах. *Тылсымланган сыман, әйтерсең лә мин тәнемнән чыгам.* Җ.Дәрзаман

2) Тылсымга баю; тылсымлы булып китү; серлеләнү. *Әмма Хәкимҗан абзыйның төрле тылсымнар белән тылсымланган билетына йөз мең түгел, ике йөз сум да чыкмады.* К.Тинчурин

3) Үзе генә белгән, яраткан эш белән шөгыльләнү, нидер маташтыру. *Айдаш карт мунчада нидер тылсымлый иде.* Р.Батулла

**ТЫЛСЫМЛА́У** *ф.* 1) Сихерләү, тылсым көче белән үзгә бер халәткә күчерү. *Шул шартларны җиренә җиткереп үтәгәндә генә, бу могҗизалы дару сине матурлар, җаныңны сафландырыр, тылсымлар, сихерләр.* Ш.Галиев

2) Үзенә карату, җәлеп итү, әсир итү. *Монда, әлбәттә, безнең Тукайга булган кер кунмас мәхәббәтебез дә роль уйнады булса кирәк, ләкин Әхмәт Фәйзи таланты да безне нык кына тылсымлады.* Казан утлары

**Тылсымлап алу** Тиз арада тылсымлау. *Барысы да мине, китап дөньясына чумып утырган япь-яшь авыл малаен, бер минут эчендә тылсымлап алды.* М.Вәлиев

**Тылсымлап кую** Тымсымланган хәлгә китерү. --- *Җәмигъ китапларын бер җиргә җыеп, бер мәгарә эченә тылсымлап куйдылар ---.* К.Насыйри

**Тылсымлап тору** Гел, һәрвакыт тылсымлау; сөйләү моментында тылсымлау

**Тылсымлый бару** Торган саен күбрәк тылсымлау

**Тылсымлый башлау** Тылсымларга тотыну. *Тылсымлый башлаганчы, башта бөтен кирәк-яракларын әзерләде карчык.* Әкият

**ТЫЛСЫМЛЫ** *с.* 1) Сихри көчкә ия булган; могҗизалы. *Аларга Җилбатырныкы кебек тылсымлы итек тә, Тамчыкайны алып киткән елгыр болыт та кирәкми.* Ф.Яруллин. *Шәүкәт, әгәр дә синең кулыңда тылсымлы таягың булса, бу минутта нишләр идең?* М.Маликова

2) *әд.* Эш-хәрәкәтләр, вакыйгалар сихер ярдәмендә башкарыла торган; фантастик. *Бары Рәфистән күзен алмыйча, аның киләчәк турындагы берсеннән-берсе матуррак, ул гына да түгел, бераз тылсымлы әкиятне хәтерләткән җилкеткеч уй-хыялларын гына тыңлый.* А.Вергазов. *Тылсымлы әкият тыңлагандай, тын да алмый тыңладылар аны.* К.Кара

3) *күч.* Искиткеч матур, сокландыргыч, күңелне биләп ала торган. *Ул тылсымлы кыллардан чыккан мөкатдәс моңнар безгә бик тә якын, бик тә кадерле.* Р.Миңнуллин. *Мондый яктылыкны, мондый тылсымлы төсләрне башка беркайда да очратырга мөмкин түгел.* М.Кәбиров

**ТЫЛСЫМЧЫ** *и.* Тылсымга, сихри көчкә ия булган кеше; тылсым, могҗиза тудыра торган кеше. *Тылсымчы булсам, бер дә шиңми торган чәчәкләр үстерер идем.* Ф.Яруллин. *Тылсымчы карт сөякне ташлады да тынып калды.* Т.Галиуллин

**ТЫЛСЫМЧЫЛЫК** *и.* Тылсым ясау, эшләү шөгыле; тылсым белән эш итү. *Исемнәре сихерчелек һәм тылсымчылык символына әверелеп, сихерчеләрнең магик гамәлләрендә киң кулланыла.* Ф.Урманче

**ТЫЛЧЫ** *ы.* Тылда эшләүче кеше. *«Хезмәт ветераны» исемен алдым, ике мәртәбә Коммунистик хезмәт алдынгы эшчесе булдым, тылчы буларак медальләрем бар.* Безнең гәҗит

**ТЫМАТ** *с. гар.* 1) *к.* **ыктымат**

2) Ипле, җайлы. *Тымат кеше икәнлеге сөйләшүеннән үк күренеп тора.* Казан утлары

3) Пөхтә, җыйнак. *Тымат бала*

4) Нык; ныклы, ышанычлы. *Татар йортын тымат нигез тота* ---. Сөләйман

**ТЫМЫЗЫК** *с.* **1.** 1) Тын, тыныч, хәрәкәтсез, җилсез (көн, һава, су һ.б.ш. тур.). *Көн тымызык.* Һ.Такташ. *Сүнеп киткән учакка чыбык-чабык ташлаштырып утырган Мөҗәһит кинәт кенә тымызык һаваны яңгыратып көлеп җибәрде: «Кара син!»* С.Сабитов. *Тымызык күлдә корт уйный ---.* А.Тимергалин

2) Бик акрын гына исә торган (җил тур.). *Әурамда тымызык җилле салкын февраль.* Т.Галиуллин. *Кайнар йөзенә*

*кичке тымызык җил бәрелде, әз генә айныта башлады.* Н.Гыйматдинова

3) Тыныч, басынкы (кеше тур). *Ул Сакмановны ихласлыгы, йомшак күңеле, ирләрчә кыюлыгы һәм үзе кебек тымызык, карун булмавы өчен ярата иде.* Т.Галиуллин

4) *диал.* Томанлы, тонык. *Алай иткәндә тымызык кына яктыны, селкенгән шәүләләрне чамалап була.* Т.Нурмөхәммәтов. *Җәйге тымызык күктә ай да, йолдызлар да күренми.* Ә.Мушинский

5) *диал.* Чәчелми калган, кысыр (җир тур.)

6) *күч.* Тыныч; үз җае белән бара торган. *Аннан соң шәһәр мохите аңа бөтенләй ят, андагы чират торулар, ыгы-зыгы, ызгыш-талаш авылның тымызык тормышында яшәгән егетнең җанын имгәтәчәк.* Р.Газиз

**2.** *рәв. мәгъ.* Акрын гына һәм үзгәрешсез, ялыктыргыч итеп. *Аның тормышы, көзге болытлы көннәр кебек, тымызык кына бара башлады.* М.Маликова. *Тымызык кына агып яткан елганың үзәне куксел яшел кыяккүрән белән капланган – үзебезнең Күрәнле!* Г.Якупова

**ТЫМЫЗЫКЛАНУ** *ф.* 1) Җил басылып, тын калу. *– Тымызыкланды кебек, әллә һава сулап, йөреп кайтабызмы, – диде ул әнисенә.* Казан утлары

2) Салмаклану; тоныклану. *Кылычларның ялтыр кырларына йолдызлардан төшкән шәүләдәй Тымызыкланып яңгырый Урал моңы – Таштугайлар көе, Шәүрәкәй.* К.Нәҗми

**Тымызыклана бару** Торган саен ныграк тымызыклану. *Парланып торган җылы һава әкренләп тымызыклана барды.* С.Рафиков

**Тымызыклана башлау** Тымызыклану сизелү. *Көн тымызыклана башлады*

**Тымызыклана төшү** Бераз тымызыклану; тагын да тымызыклану. *Августның кызу булса да инде салмаклана, тымызыклана төшкән көне әйтерсең бәйрәм оештыру өчен туган.* Казан утлары

**Тымызыкланып калу** Тымызыкланган хәлгә килү. *Тымызыкланып калган сыман тоелса да, еракта-гы тавышлар һаман ишетелә әле.* И.Нуруллин

**Тымызыкланып китү** Кинәт тымызыклану

**Тымызыкланып тору** Озак вакыт дәвамында тымызыкланган булу; сөйләү моментында тымызык булу

**ТЫМЫЗЫКЛЫК** *и.* Тымызык булу сыйфаты. *Кешенең юашлыгы, тымызыклыгы бу мәкальләрдә бер дә макталмый, бәлки ачык, туры, тәвәккәл һәм кыю булырга тиешлеге алга куела.* Мәкальләребез турында

**ТЫМЫК** *с.* Тын, җилсез; тыныч, тымызык. *Хәзер аның тымык суны дулкынлап алга омтылуы да күренә, мышнап сулыш алганы да ишетелә иде.* З.Мурсиев. *«Тымык күлдә шайтан уйный» дигән сүз бар бит...* Г.Гыйльманов

**ТЫМЫРСЫК** *с. диал. к.* **тымызык** (*1–2 мәгъ.*). *Тымырсык һава*

**ТЫН** I *с.* **1.** 1) Тавышсыз, тынлыкка (*1 мәгъ.*) баткан; шау-шусыз; тынычлык урнашкан. *Өйдә чакта тыптын булып тоелган авыл алай ук тын түгел иде.* Ф.Яруллин. *Алар төрле дулкыннарда, төрле телләрдә киләләр һәм, радиоалгыч аша үтеп, тын йортларны шом белән тутыралар.* М.Маликова

2) Җилсез, тымызык. *Моның кебек авыр, тын, хәрәкәтсез һава бары яшенле яңгыр яки көчле давыл алдыннан гына булырга мөмкин, һәм, ныграк игътибар итсәң, көн чынлап та үзгәрмәкче иде шикелле.* Ә.Еники. *Башта һава тын иде, бераздан көчле җил чыкты.* Г.Әпсәләмов

3) Әкрен; хәрәкәтсез, тыныч. *Төптә яңадан икенче агым була – әкрен, тын агым.* С.Хәким. *Күзеңне йом да тыңла: бу музыкада үз Ватаныңның шаулы урманнары, камышлы тын күлләре, чылтырап аккан чишмәләренең октавалары бар.* М.Мәһдиев

4) Кеше булмаган, кеше комачауламый торган; аулак. *Күзгә-күз карап, бер-берсенә сыенып, кар баскан тын сукмактан әкрен генә атлап китәрләр иде.* Р.Габделхакова. *Киң басуның тын юлыннан Узса уза тик игенче.* Р.Закиров // Мәдәният үзгәннән, цивилизациядән ерак. *Тын ил*

5) *күч.* Тыныч; хафаланмаучан, борчылмаучан. *Җәләл тыштан тын вә тыныч, хәтта уяулы-йокылы бер халәттә кебек күренсә дә, аның эчендә үзенә дә ачык билгеләнеп бетмәгән бер куәт кайный, нидер сыеша алмый, бәреп чыгарга итә шикелле иде.* Г.Ибраһимов. *Рәшидә дә тын, йөзе сүрән булуын сиздермәскә тырыша, тешен кыса, иреннәрен кыймылдата.* Р.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тавышланмыйча, шауламыйча; тавышсыз. *Телефон тын торды.* Х.Туфан. *Тын гына утырса да, җыерыла төшкән киң маңгае, ике уртада түбәнгә бөгелгән куе кашлары һәм ничектер аксылланып киткән чырае җанындагы киеренкелекне яшерә алмады.* А.Вергазов

2) Ярсымыйча, дулкынланмыйча; салмак, акрын; тыныч (агу, исү һ.б. тур.). *Юк, хәзер хәтерли алмый инде ул, җыр онытылган, әмма гомерендә бары бер мәртәбә татыган бәхет – Тимерҗанны өйләндереп килен төшерү бәхете – бик ерактагы ялгыз йолдыздай аның күңеле түрендә тын гына нур сирпеп һаман да балкый әле.* Ә.Еники. *Тирән сулар тын ага.* Яңарыш

3) Ишетелер-ишетелмәс, көчсез, акрын; кычкырмыйча (тавыш һ.б.ш. тур.). *Тавышы әллә нинди тын һәм моң чыга: – Без, иптәшләр, вакытлы рәвештә чигенеп торабыз, – ди ул, әйтерсең ул командир да, аны дошман гаскәре чигенергә мәҗбүр иткән.* А.Алиш. *Кыз тын гына елап утыра иде.* М.Мәһдиев

4) Борчылмыйча, дулкынланмыйча, кайгы-хәсрәтсез. *Әмма Фаягөл янында тын гына яшәрмен дә димә.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Тынычлык шартларында, сугышсыз; тыныч. *Ябырылды фашист козгыннары Ватанымның изге күгенә... Килә алар үлем яудырырга Тын яшәгән илем өстенә.* Ш.Маннур

**3.** *и. мәгъ.* 1) *сир. к.* **тынлык** (*1 мәгъ.*). *Бераз вакыт тын.* Г.Камал

2) *сир. к.* **тынычлык** (*3, 5 мәгъ.*). *Тынга чумган диярсең, гел елмаеп кына йөри ул хәзер.* Казан утлары

**ТЫН** II *и.* 1) Тере организмнарның үпкәләр белән эчкә кислород йоту һәм тышка углекислый газ чыгару процессы; сулыш. *Хәбиров траншеяның сул*

*тармагына кереп китте, тын бетсә дә, һаман йөгерде.* Х.Камалов. *Чөнки Күкчә кем икәнен оныта, артык масаеп китеп, чебен булып күзгә керә, авыр тузан булып тын юлына утыра башлый.* А.Хәсәнов

2) Сулагач, үпкәләрдән кире чыга торган һава. *Йотлыгып су эчкәч, Аксыл бүре озын тын белән улый башлады.* Р.Батулла

3) *сир*. Гомумән һава. *Алар карагач, аптыраудан авызларын ачып каттылар: арткы шиннарның икесе дә тын җибәргән иде.* Ф.Садриев. *Ләйсәнле болытлар катыннан бөркелеп, исерткеч тын килде.* З.Мансуров

4) *күч*. Сулыш алу киңлеге, мөмкинлеге; сулау сәләте. *Миңа тын җитми, миңа иркенлек җитми!* Н.Фәттах. *Кычкырасы килә бар тынга!* Г.Гыйльманов

5) Берәр кеше, берәр әйбер яки күренеш тәэсире, йогынтысы. *Сездәге космик үзәкнең яшерен тыннары да безгә килеп тора, дип әйтүнең кирәге дә юктыр.* Ф.Баттал

◊ **Тын алган тавыш та** Бернәрсә дә, өн дә (ишетелмәү, чыкмау). *Аңа сөйләргә комачаулап шаулашучылар да, сүзен бүлдерүчеләр дә булмады, ихтирам күрсәтеп, тыныч кына, тыйнак кына тыңлап тик утырдылар, ичмасам тын алган тавыш та ишетелмәде.* Н.Фәттах. *Зал тулы халык, баягыча, үзләренең кайда утырганнарын онытып, сәхнәгә йотылганнар. Тын алган тавыш та чыкмый.* М.Әмир. **Тын алганы да сизелмәү** Үзен бик тыныч тоту (бала, авыру кеше һ.б.ш. тур). *Васыйлның борылганы, хәтта тын алганы да сизелми.* Р.Рахман. **Тын алганына кадәр белү** Берәр кешенең тормышы, серләре, эшләре турында тулысынча хәбәрдар булу, барысын да белү. *Тын алганыңа кадәр белеп торабыз, бездән берни яшерә алмыйсың.* М.Галиев. **Тын алгысыз** Үтә авыр, эссе, салкын һ.б.ш. һава турында. *Мунча эче тын алгысыз эссе иде.* Р.Батулла. *Тын алгысыз авыр һавасы, кубып беткән төссез-пычрак обойлары, тузан каплаган иске телевизоры, ризык калдыклары белән тулган өстәле --- ни сәбәпледер, беркем дә күмелмәгән һәм тора бара чуп-чар белән тулган буш каберне хәтерләтте.* Ә.Дусайлы. **Тын алмастан** *к*. **тын да алмыйча** (*2 мәгъ.*). **Тын алу** Ял итү, хәл җыю. *Әбиемнең аз гына, үзе әйткәндәй, тын алырга вакыты булган арада, капка төбенә чыгып яисә койма өстенә үрелеп, хәбәр көтеп юлга, авыл башына карап торганы хәтеремдә.* Ф.Сафиуллин. *Тын алырга дип урамга – ресторан каршына чыгып баскан иде, әллә каян гына Мөнир килеп чыкты.* Х.Ибраһим. **Тын алуны онытып** *к*. **тын да алмыйча** (*1 мәгъ.*). *Тын алуны онытып карадым мин бу концертны. Браво!* И.Газиев. **Тын алырга да бирмәү** 1) Берәр эшне бик тиз, килеп чыккан хәлне уйлап торырга, аңларга, аңга килергә мөмкинлек калдырмый башкару. *Да, батькалар тын алырга да бирмиләр.* Т.Гыйззәт. *Күр, тын алырга да бирмиләр.* М.Әмирханов; 2) Ял иттермәү. *Ә район тын алырга бирми: давай, давай, чәчү турында сводка тапшыр.* Х.Камалов. **Тын алырга да вакыт бирмәү** *к*. **тын алырга да бирмәү**. *Немецлар безне бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләтергә, тын алырга да вакыт бирмичә ашыктырырга керештеләр.* Г.Галиев. **Тын алырга да вакыты булмау** Эшнең бик күп, тыгыз булуы турында. *Нишләмәк кирәк, ял итү түгел, тын алырга да вакыт юк.* М.Хәсәнов. *Көнозын анда чап, монда чап, тын алырга да вакыт юк.* Р.Ишморат. *Шулкадәр мәгълүмат җитештерүче редакциядә туктап тын алырга да вакыт юктыр, мин әйтәм.* Л.Заһидуллина. **Тын алырга да вакыты калмау** *к*. **тын алырга да вакыты булмау**. *Кыскасы, Казандагы кебек күңел кичерешләренә чумарга түгел, тын алырга да вакыты калмады.* Г.Әпсәләмов. **Тын алырга да ирек бирмәү** *к*. **тын алырга да бирмәү**. *Аларны куарга, тын алырга ирек бирмичә куарга кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Ул янындагы караучыларына тын алырга да ирек бирми.* М.Әмирханов. **Тын алырга да кыймау** *к*. **тын алырга да курку**. *Һәркем кузгалырга да, тын алырга да кыймыйча, шаккатып, елмаеп, идән уртасында бөтерелгән җанлы бөтерчекне күзәтте.* Н.Фәттах. **Тын алырга да курку** Берәр кешегә яки берәр нәрсәгә комачауламаска тырышу, бик сак булу. *Мөнирҗан, тын алырга да куркып, әтисенең җавабын көтте.* Н.Әхмәдиев. *Фәттахны зал тын алырга да куркып, кысылып, шикләнеп тыңлады.* Р.Батулла. **Тын буылу** *к*. **тын киселү**. *Аннан, Германия туфрагына аяк басуга, тын буыла башлады.* М.Мәһдиев. *Мин сине озатырга бара алмадым, чөнки минем үз хәлем дә шәпләрдән түгел: унунбиш адым барган саен, тын буылудан туктарга туры килә.* Көндәлек язмалар. **Тынга кабарлык** *к*. **тын алгысыз**. *Чатнап торган январь төне. Тынга кабарлык булып куе сыкы төшкән.* М.Хәсәнов. **Тын да алдырмау** *к*. **тын алырга да бирмәү**. *Тын да алдырмыйсыз бит сез, берсе артыннан берсен кушып кына торасыз.* Г.Әпсәләмов. **Тын да алмыйча** 1) Бик нык бирелеп, игътибар белән (карау, уку, тыңлау һ.б.ш. тур.). *Зал тын да алмыйча тыңлый.* З.Зәйнуллин. *Таһирҗан картның ни әйткәнен аңлап бетермәсәләр дә, барысы да, тын алмыйча, аны тыңладылар.* Ф.Бәйрәмова. *Аның язганнарын Ирек тын да алмыйча укырга кереште ---.* Ф.Садриев; 2) Берьюлы, ял да итмичә, тукталмыйча (эшләү, сөйләү һ.б.ш. тур.). *Төннең-төн буена тын да алмый сөйләшеп чыкты алар.* Г.Галиева. **Тын да тартмыйча** *к*. **тын да алмыйча** (*1 мәгъ.*). *Ул, әнигә борылып, тын да тартмыйча сөйләп китте: – Мине гафу итегез.* Ф.Баттал. **Тын да чыгармау** 1) Бер сүз әйтмәү, эндәшмәү, сөйләшмәү; 2) Тавышланмау, шау-шу күтәрмәү. *Телевидениедән татар тапшыруларын елдан-ел кыскарталар, тын да чыгармыйбыз.* А.Хәсәнов. *Түзде, тынын да чыгармады.* М.Әмирханов. **Тын җыю** Бераз ял итү, хәл алу. *Җырның берсен тәмамлап, икенчесен башларга тын җыеп торганда, читтәнрәк яшь бер тавыш кычкырып җырлап җибәрде: «Җилләр исә, җилләр исә, җилгә бөгелә гөлләр; Безгә түгел, дошманга да Килә ул кара көннәр!»* М.Маликова. *Эш эшләп бетердеме, ул тын җыяр өчен урамга чыкса, анда аны кинематограф каршы ала.* Казан утлары. **Тын кабу** *к*. **тын кысу**. *Аннан*

*тын кабып егыласың да, хәл алгач, мактаныша башлыйсың: – Ә мин бер җир буе арттагы калаена тотынып бардым.* М.Мәһдиев. **Тын каплану** *к.* **тын буылу**. *Гүр газаплары белән узган юлны янә үтергә кирәклеген аңлагач, аянычтан тын каплана.* Р.Батулла. *Тын капланган, сүзләребезне әйтә алмый тордык...* Бу тормышта ниләр бар? **Тын киселү** Үлү. *Иптәшләре үлә берәм-берәм: Ташлар басып, туфрак ишелеп яки, караңгыда эшли торгач, хәлдән таеп, тыны киселеп.* М.Гафури. **Тын куыра торган** *к.* **тын куыргыч**. *Ул тавыш, әллә ничек шунда, сугыш кырыннан килгәндәй тоела, бәлки, чыннан да, тын куыра торган җил ул тавышларны монда сугыш кырыннан ук алып киләдер.* М.Мәһдиев. **Тын куыргыч** Сулыш алуны авырайтырлык яки бөтенләй туктатырлык (салкын җил, сүз һ.б.ш. тур.). *Тагын тын куыргыч авырту!* Сөембикә. **Тын куырылу** Авырлык белән сулыш алу. *Халык кайный, Сабантуй умарта күчедәй гөжли, эсседән баш әйләнә, тын куырыла.* Р.Камал. **Тын кысу** Бик каты йөгерүдән, әсәрләнүдән яки бик нык салкыннан, эсседән һ.б.ш. сулыш алу авыраю, туктау. *– Тын кыса, Гөлшаһидә, – дип зарланды профессор, бераз менгәч тә туктап.* Г.Әпсәләмов. *Юк, тын кысмый, ярсу йөрәгемне һәм җанымны сагыш-моң кочә!* Р.Закиров. **Тын кысылу** *к.* **тын кысу**. *Мөгаен, бу минутта аның гына түгел, бүтән бик күпләрнең дә тыннары кысылган булгандыр.* Г.Әпсәләмов. *Маңгайдан аккан тир күзләрне әчеттерә, юешләнгән күлмәкләр тәнгә ябыша, тын кысыла, аяк-кулның хәле бетә, тамаклар кибә.* З.Зәйнуллин. **Тыннарын кысып** *к.* **тын да алмыйча** (*1 мәгъ.*). *Барысы да, тыннарын кысып, аның авызына текәлделәр.* Н.Фәттах. *Тыннарын кысып озак чаптылар.* Х.Камалов. **Тыннарын чыгартмау** Кемгә дә булса каршы сүз әйтергә, ярамаган эш эшләргә мөмкинлек, ирек бирмәү. *Нинди рөхсәт итү? Тыннарын да чыгартмабыз без аларның.* Казан утлары. **Тынны арттан алу** *к.* **тынны эчтән алу**. *Синнән такылдавык кеше булмыйдыр иде дә бит, хәзер телеңне тешләп, тыныңны артыңнан алып тик утырасың инде.* М.Фәйзи. **Тынны буу** Сулыш алуны кыенлаштыру, авырайту. *Ул мәхәббәт хисе тынны буа, башны әйләндерә, тамак төбен киптерә иде.* М.Мәһдиев. *Ясак салып, кол хәлендә калдырылгач, Тынны буып, хак динеңнән яздырылгач, Башны ташка орсаң да син, юк һич чара, һәр адымың сак астына алдырылгач.* С.Әхмәтҗанова. **Тынны куыру** 1) *к.* **тынны буу**. *Салкын һава тынны куырды, тән калтыранды, кире әйләнеп, җылы, тынчу вагонга керәсе килде.* М.Маликова. *Тынны куырып, керфек-кашларыңны бозга катырып уза бездә буран.* Д.Бүләков; 2) Сөйләү сәләтен югалтырлык итеп әсәрләндерү. *Кыланмышларына түзәр чамам юк, тынны куыра.* М.Мәһдиев; 3) Җәфалау, интектерү. *Сорау алулар аның тынын куырды, тәмам хәлсезләндерде.* А.Гыйләҗев. **Тынны эчтән алу** Берәр кешедән, берәр нәрсәдән бик каты курку, шүрләү. *Уяныр иде халык калтыранып, хәйран калып, Көтәр иде әйтәчәк сүзне, тынын эчтән алып.* К.Нәҗми. **Тын өрү** Көч бирү; көч өстәү. *Олимп уты ягар чакта, сүнеп барган учагыңа тын өрергә кирәк безгә.* Р.Фәйзуллин. **Тын тарту** Организм нормаль хәлгә килү; хәл алу. *Күңелен урынына куеп тын тарткач, Сәет сүзен җитди итеп төгәлләде: – Миңа озак вакытлар ул җитмәс.* Т.Галиуллин. **Тын тартырга курку** *к.* **тын алырга курку**. *Ул абына-сөртенә өйгә керде, бусаганы атлап узгач, тын тартырга куркып тыңланып торды.* А.Гыйләҗев. **Тын тоту** *к.* **тын кысу**. **Тыны бетү** *к.* **тын куырылу**. *Ә йөрәк кагу, тын бетү, аяклар җилсенү ишесе мондый чакта күпләрдә була.* М.Маликова. *Катырак кыскандыр: тын бетте, колаклар чыңлады, йөрәк атылып чыгардай булып типте, маңгайга тир бәреп чыкты.* Казан утлары. **Тыны да чыкмау** *к.* **тынын да чыгармау**. *Мин кырыйларына кәс тезгән яңа кабер янында басып торганда, Музгаркамның тыны да чыкмады, әйтерсең лә ул да бу мизгелнең мөһимлеген аңлый иде.* А.Тимергалин. *Күрше республикаларның тыны да чыкмый.* Р.Миңнуллин. **Тыны кату** Бик нык курку. *Ул күренүгә, сабыйлар, тыннары катып, өйләренә йөгерделәр.* Ф.Баттал. **Тынын да тартмый** *к.* **тын да алмыйча**. *Гаиләбез, тынын да тартмый йотылып тыңлый-тыңлый, рәхәт йокыга китте.* Ф.Яхин. **Тынын да чыгармыйча** 1) *к.* **тын да алмыйча** (*1 мәгъ.*). *Немецлар тыннарын да чыгармыйча утыралар, хәтта ракеталары да теләр-теләмәс кенә оча.* Г.Әпсәләмов. *Бераздан Бикчәнтәев әзер пьесаны актёрларга укый, тегеләре исә тын да чыгармыйча тыңлыйлар, аңлашылып тора: бу чыннан да сезонның хиты булачак!* Г.Зәйнуллина; 2) Бер сүз әйтмичә, эндәшмичә. *Әйтерсең кара уйлар белән уралган да ул, тынын да чыгармый шыпырт кына ята.* С.Зыялы. **Тынын эчкә тарту** *к.* **тынны эчтән алу**. *Аучылар, тыннарын эчкә тартып, кошларга якынлашалар.* А.Гыйләҗев. **Тынын эчтә саклау** Беркемгә берни сиздермәү, сер бирмәү; шыпырт кына эш итү. **Тының да чыкмасын** *к.* **тыныңны чыгарасы булма**. *Минем өемдә тының чыкмасын!* А.Гыйләҗев. *Динең, телең, халкың бетсә бетсен, дәшмә, түз, тының чыкмасын!* З.Зәйнуллин. **Тыныңны чыгарасы булма** Каршы сүз әйтмәскә, үз фикереңне белдертмәскә, бөтенләй дәшмәскә кушу. *Тыныңны чыгарасы булма, елан!* Т.Гыйззәт. *Герман киң учы белән каты итеп аның авызын томалады: – Тыныңны чыгарасы булма!* М.Маликова. **Тыныңны чыгарма** *к.* **тыныңны чыгарасы булма**. *Аппак турында тыныңны чыгарма!* Н.Фәттах. **Тын эчү** *бор.* Ял итү, хәл җыю

**ТЫН** III *и.* *к.* **тың**. *Сугыш вакытында кешедән хат килми башласа, «тынга йөриләр» иде. Беренче очраклы ишетелгән сүзне тыңлап юрыйлар.* Ш.Галиев. *Тын тыннау, тынга чыгу – нардуган көннәрендә тыңлап йөреп күрәзәлек итү, юраулар.* Татар халык иҗаты

**ТЫНА** *и.* *диал.* 1) Тапкыр, мәртәбә, кат

2) Вакыт арасы, ара, чак. *Куй, үлем! Калдыр мине, куй, борчыма! Җырлыйсым бар бу җирдә бер тына!* Н.Исәнбәт

**ТЫ́НАЛЫШ** *и.* Ял итү, хәл җыю өчен кыска вакытлы тукталыш. *Бераз тыналыштан соң, сер сөйләргә җыенган кешедәй, --- [ул] тавышын кыса төшеп әйтте.* Ф.Хөсни

**ТЫНАП** *и. диал. к.* **тына** (*1 мәгъ.*). *Мин разыймын мәңгегә, каршымда бер талпын гына. Бер тынап елмай да күңелемнең күген яктырт кына.* Г.Сәмитова

**ТЫНАЮ** *ф. диал.* Тын алу, хәл җыю. *– Бераз тынайгач дәвам итәрмен юлны, бер дә хәлем калмады, – диде ул, кулларын уа-уа.* Т.Гыйззәт

**ТЫН-БАШ** *җый. и.* Тын, сулыш; хәл

◊ **Тыны-башы бетү** Сулышы авыраю, тыны кысылу. *Тыны-башы беткән бабасы килеп кергәч, малай куркып китте.* М.Мәһдиев. *Гата карт исәнлек-саулык та сорашмады, тыны-башы бетеп, үртәлеп-калтыранып, туп-туры сүзгә башлады.* Н.Фәттах

**ТЫН-БУ** *җый. и. к.* **тавыш-тын**

◊ **Тыны-буы чыкмау** Дәшмәү, һич тавыш бирмәү. *– Җыелышта андый вакытта хәтта синең дә тының-буың чыкмый әле, – дип төрттерде ул.* И.Гази

**ТЫНГЫ** *и.* 1) Рухи тынычлык, борчусыз, ярсусыз булган халәт. *Минә дүрт ай инде аның тынгы күргәне юк, дүрт ай инде күңелен әле утка салган, әле боздай өшеткән тойгылардан арына алганы юк.* М.Маликова. *Урамнан уйнап кайткач та тынгы юк миңа.* К.Кәримов

2) Тыныч, борчылусыз, борчумәшәкатьсез тормыш. *Миңа көндез дә тынгы юк.* Х.Камалов. *Ыруга кайтса, аның белән беркемгә тынгы булмаячак, анасы Койтым бикә барыбер аның яклы булачак.* Н.Фәттах

◊ **Тынгы белмәү** Һәрвакыт эштә-хәрәкәттә булу, ни белән дә булса мәшгуль булу; тынгысыз булу. *Тынгы белмәс Диниснең үз сүзе сүз: – Юк, яшьти, мондый өйгә килде-китте генә тәрәзәләр ярамый.* М.Хәсәнов. *Моныснең да рәисе – тынгы белмәс, энергиясе ташып торган шул ук Кави Нәҗми.* Р.Низамиев. **Тынгы бирмәү** Кемне дә булса борчып, тынычсызлап, бимазалап тору; тынычлык бирмәү. *Әмма безнең самолётлар тынгы бирмиләр, эзәрлекләп, башларына пулемёттан ут яудыралар иде.* Х.Камалов. *Күрәсең, бу сүзләр инде күптән тынгы бирми иде аңа.* Х.Ширмән. **Тынгы табу** Рухи тынычлык табу, тынычлану. *Өйдә тынгы таба алмый, ул менә тагын кәҗәсен эзләргә чыкты.* А.Хәлим. *Җирдәгене белмисең, шуңа җаның тынгы тапмый.* М.Маликова

**ТЫНГЫЛЫК** *и. к.* **тынгы**. *Ләкин малайлар аңа тынгылык бирмәделәр.* М.Хәсәнов. *Теге язу аңа һич тынгылык бирмичә, күз алдында бөтерелде дә бөтерелде.* Ф.Җамалетдинова

**ТЫНГЫЛЫКСЫЗ** *с. сир. к.* **тынгысыз**. *Мин синең тынгылыксыз кеше икәнеңне беләм инде, Саттар абый.* Ә.Фәйзи

**ТЫНГЫСЫЗ** *с.* **1.** 1) Үзенә дә, башкаларга да тынгылык бирми торган, һәрвакыт берәр эш, сүз яки фикер белән мәшгуль; тиктормас. *Ләкин Газинурның тынгысыз җаны бу гомуми кагыйдәгә дә сыярга теләми иде.* Г.Әпсәләмов. *Ә алар нәселе, алар ягы бик тә тынгысыз, хәтта артыгы белән тынгысыз һәм, минем аңлавымча, эшлекле кешеләр булган.* М.Вәлиев

2) Бер урында тик кенә, тын тора алмый торган, башкаларны борчый торган. *Ул коеның файдасыннан күбрәк зыяны тигән: йөгереп уйнап йөрүче тынгысыз малай коега егылып төшә һәм аягын имгәтә.* К.Миңлебаев. *Тынгысыз Габделбәр баракның бер почмагында баядан бирле кыштыр-кыштыр килә.* А.Хәсәнов

3) Гел хәрәкәттә булган, ярсу. *Инде ни күнеккән Марина да сукрана иде, чөнки, стеналарга, почмакларга бәрелеп, аның да тәне күгәреп бетте: диңгезнең бик тә тынгысыз чагына туры килделәр.* М.Маликова

4) Борчулы, бимазалы, мәшәкатьле, тынычсыз. *Чыннан да, аның гомере тынгысыз иҗатта, халык язмышы белән бәйләнешле кичерешләрдә кайнап уза.* Х.Туфан. *Тик адәм баласының йөрәге һәрчак тынгысыз.* Г.Сабитов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тынычсыз рәвештә; борчулы хәлдә; мәшәкатьләнеп. *Тагын Рәшидәнең ике каш арасы җыерылып, нечкә кашлары тынгысыз тибрәнеп куйды.* Ә.Еники. *Күзләре ничектер тынгысыз ялтырый.* С.Сафиков

**3.** *и. мәгъ.* Тынгысызлана торган, тынычсыз кеше. *Тынгысызларга, ашыгып яшәүчеләргә әҗәле дә сәеррәк килә шул.* Л.Шәех

**ТЫНГЫСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Тынычсызлану. *Гатаның шашкын йөрәге шул Эльзаны эзләп кенә тынгысызланган икән.* М.Мәһдиев. *Болай борчылырга, тынгысызланырга һичнинди җирлек юклыкны яхшы белә ләбаса Расих?* Ф.Яруллин

2) Тынычсызлану, бер урында тик тормау, тыныч тормау. *Атлар тынгысызлана.* М.Хәсәнов. *Тынгысызланып пошкырына башлаган арык атны су эчәргә алып барасы бар иде аның.* Г.Гыйльманов

**Тынгысызлана бару** Торган саен ныграк тынгысызлану. *Аптырагач, балконга да чыгып керде, киштәдәге китапларны да санап карады, әмма күңеле урынына утыра алмыйча, торган саен тынгысызлана гына бара иде.* Р.Вәлиев. *Әмәт тавына якынлашкан саен, Тәңгәрәйнең йөрәге тынгысызлана барды.* Г.Гыйльманов

**Тынгысызлана башлау** Тынгысызланырга тотыну. *Якын килә башладымы, атлар аңардан куркып кала, колагын шәмрәйтеп тынгысызлана башлый, урмандагы берәр ерткыч якыная диярсең.* Р.Низамиев

**Тынгысызлана төшү** Бераз тынгысызлану; тагын да тынгысызлану. *Әби, безнең сүзгә ышанмады ахры, тагын да тынгысызлана төште.* Г.Сабитов

**Тынгысызланып алу** Аз гына тынгысызлану; берара тынгысызлану. *Тикшерү вакытында бик каты тынгысызланып алдык әле.* Сөембикә

**Тынгысызланып йөрү** Гел тынгысызлану; озак вакыт дәвамында тынгысызлану

**Тынгысызланып калу** Тынгысызланган хәлгә килү. *Шулай да Сафуан Микулайның бу кереп чыгуыннан тынгысызланып калды.* З.Мәхмүди

**Тынгысызланып китү** Кинәт тынгысызлану

**Тынгысызланып тору** Гел тынгысызлану. *Әмма, бара алмыйм, нигәдер*

*йөрәк тынгысызланып тора, диде ул.* Казан утлары

**ТЫНГЫСЫЗЛА́У** *ф. к.* **тынычсызлау**. *Чөнки бу бит аларны тынгысызлау, кыймылдарга мәҗбүр итү була!* М.Вәлиев. *Минә күкрәктәге снаряд кыйпылчыгы гына кайвакыт тынгысызлый.* З.Хәким

**Тынгысызлап алу** Аз гына тынгысызлау. *Бу үзгәрешләр институт хезмәткәрләрен тынгысызлап алды, әлбәттә.* М.Мәһдиев

**Тынгысызлап йөрү** Гел тынгысызлау; озак вакыт дәвамында тынгысызлау. *Әмма, Фәхри Хисами әфәндене ректор үз бүлмәсенә дәштереп чәй эчерә икән, сөйләшәләр, дигән сүз күпләрне тынгысызлап йөрде.* Ф.Яхин. *Ничек инде аларны тынгысызлап йөрисең!* Ватаным Татарстан

**Тынгысызлап тору** Әледән-әле, һаман тынгысызлау. *Башым тынгысызлап тора, кая, бераз капшап ал әле.* Т.Гыйззәт. *Аннан соң өзлексез аның күңелен бер уй, бер кайгы, борчу тынгысызлап торды.* Н.Фәттах

**Тынгысызлый башлау** Тынгысызларга тотыну. *Аның күз алдына әле күңелле, гүзәл күренешләр килде, әле куаныч күгендә кара болытлар кабарып чыкты да, күңел кылларын ниндидер курку-өркүләр тынгысызлый башлады.* Н.Фәттах

**Тынгысызлый бирү** Тынгысызлавын дәвам итү; бернигә карамый тынгысызлау. *Яңа җитәкче үзе дә тынгысыз, безне дә һаман тынгысызлый бирә.* Г.Гариф

**ТЫНГЫСЫЗЛЫК** *и.* Тынгысыз булу үзенчәлеге. *Иҗат – гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул.* Х.Туфан. *Ахыр чиктә агай-энене тәкате бетте ахрысы, һәрбер хәрәкәтендә көч-гайрәт, ашкыну, килеш-килбәтендә ихтыяр көче һәм әллә ниткән тынгысызлык ташып-бөркелеп торган солдатка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды.* М.Хәсәнов

**ТЫНДЫРУ** *ф.* 1) Тынычландыру, тыныч халәткә китерү, борчуны тарату. *Яза шагыйрь каләм сындырганчы, Бунтарь җанын тәмам тындырганчы.* Җ.Дәрзаман. *Тик Ходай җанны тындырыр микән?* Н.Гыйматдинова

2) Кемне дә булса тынычлыкта калдыру, борчудан, йөдәтүдән туктау. *Сине дә тындырмый Беренче, миңа да тынгы юк.* Ф.Сафин. *Бала хәсрәте җанны тындырмый.* Р.Камалетдинова

3) Кешеләргә яки җанлы-җансыз нәрсәләргә ял бирү, ял иттерү. *Сөләйман белән карчыкның улы, утырып, арыган аякларын бераз тындырырга уйладылар.* К.Тинчурин. *Бер-бер артлы гел эш кушып тора, бер дә тындырмый безне Әлмира ханым.* Ватаным Татарстан

4) Нәрсәне дә булса һәрвакыт эшләтеп, кулланып һ.б. тик тотмау. *[Бритваны], бала-чага бик тындырмагач, сандыкка салып куйган идем, хәзер алып бирермен.* М.Әмир

**Тындырып алу** Бераз, аз гына вакытка тындыру. *Кыш көне бераз тындырып ала да, язын тагын башлана инде ул бакча эше.* Сөембикә

**Тындырып тору** Билгеле бер ара тындыру; вакытлыча тындыру. *Әйе, табигате бик ямьле булса да, авыл үзе чыраена үлем төсе кергән хастаны хәтерләтә иде: шөгыльсезлектән аптыраган балалар, кулларын тезенә салып оешып утырган карчыклар, саф һава сулап, шау-шудан колакларын тындырып торырга дип кайткан шәһәр кешеләре.* М.Маликова

**ТЫН-КӨН** *җый. и. к.* **тын-өн**

◊ **Тыны-көне бетү** 1) Бик нык йөгерүдән яки әсәрләнүдән көчкә-көчкә генә сулыш алу; сулышы кабу. *Шулчак яралылар тезелешеп яткан олаулар янына, тыны-көне бетеп, бер яшь кенә партизан йөгереп килде.* М.Хәсәнов. *Бераздан тыны-көне беткән Фирдания кайтып та җитте.* Н.Әхмәдиев; 2) Бик нык, бик каты, бар көченә. *Ләкин мин, күз яшенә манылып яткан хатынны калдырып, бу урыннан тизрәк ычкыныйм дигәндә, ул җиңемә асылынды да тыны-көне бетеп кычкыра башлады: «Я сез үләсез, я урем...»* Ватаным Татарстан

**ТЫНЛАНУ** *ф. иск. к.* **тыну** (*1, 6, 7 мәгъ.*). *Шул рәвешле бер болгана, бер тынлана, Шул рәвеш әкрен-әкрен гомер үтә...* Ш.Бабич. *1970 нче елларда шигърият, образлылык хасиятен, романтик дәртен, эчке егәрен саклаган хәлдә, үз ярларына кайтып төште, тынланды, фикер белән хис бердәмлеген ныгытты.* Әдәбият

**Тынлана төшү** Тагын да тынлану; бераз тынлану. *Тирә-як тагын тынлана төште.* М.Гафури

**ТЫНЛЫ** *с.* Тын, сулыш өрелә торган; һава өреп уйнала торган (оркестр, музыка уен кораллары тур.). *Ә ачык форточкадан тынлы оркестр тавышы ишетелә.* И.Салахов. *Тынлы, кыллы, бәрмә, бакыр һәм агач инструментлар, оя-оя булып, оркестр чокырында бер тирәгәрәк урнашканнар.* Р.Низамиев

**ТЫНЛЫК** *и.* 1) Бернинди дә тавыш, шау-шу булмау хәле. *Тирә-якны сәер тынлык биләп алды.* Г.Галиев. *Шул рәвешле залның бер башында болганыш булып алды, дәрәҗәле тынлык бозылды, бөтенесе хәрәкәткә килде.* М.Маликова

2) Тымызыклык, хәрәкәтсезлек. *--- авылның кичке тынлык вә хәрәкәтсезлеге, читләрдәге кырларның еракерак сузылган көе, буш вә җансыз, тын гына ятулары гаҗәп бер моңлы гармония тәшкил итә иделәр.* Ш.Камал. *Шундый ук сихри таң алды, шундый ук әкияттәгедәй гүзәл Шушма буе, шундый ук мөкатдәс тынлык һәм күңелдә өмет уты көйрәткән су агымы.* М.Хәсәнов

3) *филос.* Чынбарлыкта предметларның чагыштырмача хәрәкәтсезлеге, тик торышы. *Чынбарлыкта тик тору, тынлык (покой) бармы?* М.Абдрахманов

4) Нинди дә булса эшчәнлек, хәрәкәт һ.б.ш.ның туктап торган вакыты. *Тынлык вакытында күпсанлы вулканнар Җир өслеген калын гранит катлам белән каплый.* Фән һәм тел. *Кибетләрдә бушлык, кесәләрдә тынлык, күңелләрдә – өметсезлек дәвере.* Татарстан яшьләре

5) Үсемлектә, орлыкта матдәләр алмашы тукталып торган вакыт. *Тынлык чоры*

6) Һәлак булганнарны җәмәгать белән тын гына аягүрә искә ала торган

вакыт (гадәттә бер минут чамасы). *Гомәровның бүгенге бәхетле тормышыбыз хакына башларын салган авылдашлар хөрмәтенә куелган обелискка борылырга чакырып биргән командасы яңгырады, каһарманнарны бер минут тынлык белән искә алу һәркемне дулкынландырды.* Т.Нәҗмиев

7) *күч.* Сугыш хәрәкәтләре бераз кимү яки вакытлыча тукталып тору күренеше. *Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә.* Ә.Еники. *Ладога буенда урманда тирән тынлык.* Г.Әпсәләмов

8) *күч.* Кемнән дә булса җавап, хәбәр, теге яки бу эш-гамәлгә, сүзгә карата реакция һ.б. булмау. *«Рәхмәт, шагыйрь» дигән шигыре өчен рәхмәт әйтеп хат язган идем дә – тынлык.* Н.Нәҗми

**ТЫНМАС** *с. кит.* 1) *к.* **тынгысыз**. *Чит җирләрдә җәфа чигеп йөрдем, Юата алмый тынмас җанымны.* Ф.Зыятдинова. *Эштән арыган, ыгы-зыгыдан туйган авыл егетләре һәм тынмас ирләре дә инеш ярларына елышканнар, балык чирттерәләр.* Ф.Яхин

2) Тынмый торган. *Тынгысыз кыңгырау, Уяу әдәби кыңгырау, Уяу һәм тынмас әдәби дәү кыңгырау син!* Х.Туфан. *Борынгыдан килгән тынмас ашкыну уяна.* Ш.Галиев

**ТЫНМАСТАН** *рәв.* Бертуктамыйча, бертуктаусыз; ял итмичә. *Тынмастан җил исә. Тынмастан яңгыр ява*

**ТЫН-ӨН** *җый. и.* Тын, сулыш, тавыш-тын. *Тыны-өне юк баламның!* А.Гыйләҗев. *Почмактагы караватта яткан яралының тыны-өне юк.* Х.Камалов

◊ **Тыны-өне бетеп** Бик нык йөгерүдән көчкә-көчкә генә сулыш алып. *Капка ачылды, озак та үтмәде, аш өенә, тыны-өне бетеп, Наилә килеп керде.* А.Гыйләҗев. *– Анда ике зур таш йорт бар, шуннан аталар, – диде, тыны-өне бетеп, сулышын көчкә ала-ала.* Х.Камалов

**ТЫН-СӨР** *җый. и. к.* **тын-өн**. *Тыны-сөре юк*

◊ **Тыны-сөре бетеп** *к.* **тыны-көне бетеп**. *Тыны-сөре бетеп, бүрегенең алдын артка кигән Кадыйр бабай килеп җиткәндә, эшләр харап иде.* Казан утлары. *Тыны-сөре бетеп, әти кайтып керде, шунда ук кемдер ишек дөмбердәтә башлады ---.* Кызыл таң

**ТЫНСУ** *с.* Тавышсыз, җилсез, тын, тыныч. *Нигә шулай тынсу икән, ямансу һәм моңсу икән Сөн буйларында?* Җыр. *Нинди яз бу? Әйтәлмим лә... Ниндидер бу... тынсу, моңсу яз.* Х.Туфан

**ТЫН-СУЛЫШ** *җый. и.* 1) Гомумән сулыш. *Кешенең аһ-зарын тынсулышыннан, күз карашыннан тоярга, аңларга өйрәнгән ул.* Г.Гыйльманов. *Алар түгәрәкләнеп басканнар да, башларын түбән иеп, урта бер җирдә, карлы салам өстендә, хәлсез, җансыз булып яткан бала кисәгенә җылы тынсулышларын өреп, пар-бу бөркеп торалар...* Безнең гәҗит

2) *күч.* Җәмгыятьтәге актуаль фикерләр; шул чорда яшәгән кешеләрнең фикер сөрү юнәлеше, рухи халәте, гомуми кәеф, атмосфера. *Заманнарның тынсулышы кайнар!* Зөлфәт

**ТЫНСЫЗ** I *рәв.* Эндәшмичә, бернинди тавыш-тын чыгармыйча, шаушусыз. *Әнә шунда теге карчык читлек эчендәге жирафны күргән дә, байтак тынсыз торгач, моның булуы мөмкин түгел, дигән.* М.Мәһдиев. *Барысы да нәрсәдер буласын көтеп тынсыз калдылар һәм әле ис китмәүчән-тыныч кыяфәтле Инсафка, әле ачулы, бозылган йөзле Мәрдәнша агайга карапкарап алдылар.* Н.Фәттах

**ТЫНСЫЗ** II *рәв.* Сулышсыз, суламыйча, сулыш алудан мәхрүм. *Кыйный торгач, Коля тынсыз калган, хәтта аның сулыш алганы да сизелмәгән.* Ә.Сафиуллин. *Егылгач та торырга ашыкмады, нишләптер тынсыз калды.* Р.Габделхакова

**ТЫНСЫ́З ИТҮ** *ф.* 1) Сулышсыз калдыру, сулышка зыян китерү, сулышны туктату. *Авылга кунакка килгән, сырадан бәхәсләшеп, карлыгач ояларын җимерүче, балчык атып уйнаучы эшлексез үсмерләр кешегә карата да кансыз булып чыгалар: аларга каршы төшкән Гайнанның башына каты әйбер белән бәреп, аны тынсыз итәләр.* Ф.Хатипов

2) Үтерү. *«Яхшылык белән Мәгъсүмәне миңа бирмәсәгез, икегезне тиң тынсыз итәм!» – дип, наганын чыгарып төзәгәч, теге бичаралар берсүзсез риза булганнар ---.* В.Нуруллин

3) Берәр сүз, көтелмәгән хәбәр, вакыйга нык гаҗәпләндерү, аптырашта калдыру, гадәти халәттән чыгару. *Бу яңалык классны тагын тынсыз итте.* М.Мәһдиев

4) Каршы сүз әйттермәү, сөйләргә ирек бирмәү; авызын томалау. *Шул арада ире моны тынсыз итәрдәй бер җөмлә әзерләп куярга өлгерә.* Татарстан яшьләре

**ТЫНСЫ́З-ӨНСЕЗ** *рәв.* Җанлылык билгеләре булмагандай. *Аңа кул сузу түгел, хәрәкәтләнә дә алмыйча, тынсыз-өнсез торган Айсинәгә карап, Гөлсәрия йөзенә мыскыллы елмаю чыгарды да: «Син нәрсә, әллә миңа үпкә саклыйсыңмы», – диде.* Н.Көбәш. *Тынсыз-өнсез яткан песнәк кузгалырмы дип, кызлар түбә буйлап су агызып җибәрделәр.* М.Әхмәтшина

◊ **Тынсыз-өнсез калу** *к.* **тынсыз калу**. *Галимәне күрү белән, барысы да тынсыз-өнсез калдылар.* Н.Фәттах. *Каушавыннан бераз тынсыз-өнсез калып торганнан соң, бер ел буе йөрәгендә йөрткән сөю хисен бер матур сүзгә ияртеп, күңел читлегеннән очырып чыгарып җибәрде: – Зөһрә!* Г.Гыйльманов

**ТЫН-ТАВЫШ** *җый. и. к.* **тавыштын**. *Әмма йоклый бар табигать тын-тавышсыз, сак кына...* Г.Сөнгати. *Урамда тын-тавыш юк*

**ТЫН-ТАВЫШСЫЗ** *рәв.* Дәшмичә, гомумән, бернинди тавыш чыгармыйча. *Шунда керә дә, кармак ыргытып, тын-тавышсыз утыра.* Ә.Моталлапов

**ТЫНУ** *ф.* 1) Сөйләшүдән, җырлаудан, кычкырудан һ.б.ш. тавыш чыгарудан туктау, тын калу. *Салих тынды, минем аңа туп-туры карап утыруыма уңайсызлангандай, башын бераз гына читкә дә борды.* Ә.Еники. *Сыңар куллы яңадан сөйли башлагач, зал тынды.* М.Мәһдиев

2) Берәр төрле тавыш ишетелми, яңгырамый башлау; туктау, өзелү. *Зәйнәп ак камыр кебек кыска буынлы, юантык кулларын шактый каралган чүпрәккә сөртә-сөртә килеп чыккач, күз карашлары җылынды, тавышлар тынды.*

А.Гыйләҗев. *Рушад, бу музыкага әсәрләнеп, койма буена үрелде – музыка тынды.* М.Мәһдиев

3) Берәр эш-хәрәкәттән туктау; гомумән, хәрәкәтләнүдән туктау, нәрсәдер эшләү уеннан кире кайту, ниятеннән ваз кичү. *Наилә тынмас, подъезд юар, инде соң чиккә җитсәләр, шәл бәйләп сатар.* А.Гыйләҗев. *Берәрсе каршылык күрсәтсә, тыңламаса, ул нишләгәнен белештерми, әлеге көч каршысындагы киртәне җимерми торып тынмый.* Ф.Садриев

4) Ял итү, хәл җыю. *Ул өченче каткa хәтле һичбер тынмыйча күтәрелде.* Г.Әпсәләмов. *Ире бала карады, Хәерлебәнат тынмыйча иртә-кич эштә булды.* А.Гыйләҗев

5) Көчсезләнү, бетү, басылу, туктау (табигать күренешләре тур.). *Шул ук мизгелдә карлы-бозлы яңгыр тына, кояш чыгып, җир йөзе шатлангандай була.* Ф.Хуҗин. *Еламсак җил тына, җирдән шуышып, каядыр китеп сызгыра.* Х.Ширмән

6) Җан, йөрәк, күңел берәр хистән, борчудан, дулкынланудан арыну, тынычлану. *Күңел сыза, тынмый, Сыза борчылмыйча, көймичә, Йөрәк тагын сөя, чөнки булмый, Булдыра алмый йөрәк сөймичә.* С.Сабиров. *Эшнең асылын белми җан тынмый инде.* М.Маликова

7) Берәр күренешнең интенсивлыгы бетү, әкренләп юкка чыгу. *Урамдагы сүзләр, гайбәтләр акрынлап тынды.* Г.Галиев

8) Берәр нәрсә турында үз фикерен әйтүдән туктау, тыелу. *Нишләсәм дә эшләдем... Тик син сорашма – мин тыныйм.* Ф.Бурнаш. *Мин шул көнне үк тындым, башка берни дә әйтмәдем аларга.* И.Нуруллин

9) *күч.* Ярсудан, борчылудан, дулкынланудан туктау; тынычлану. *Каты эчү һәм өшәнүдән соң ул бер-ике көн өйдә ята. Тына, юашлана, Фираясына да әзрәк сырпалана.* Ә.Еники. *Кайткан саен ул кырларга чыга, җитдиләнә, тына, уйлана.* Р.Миңнуллин

10) *күч.* Сугыш хәрәкәтләре бераз киму яки вакытлыча тукталып тору. *Аның бәхетенә каршы, сугыш тынган чак иде, бары тик уяулыкны сиздерер өчен генә, кемнәрдер сирәк-мирәк аткалап куялар иде.* Г.Кутуй. *Фронтта, сугышлар тынган арада, Рәшит шул үткәннәрне һаман исенә төшерә торган иде.* Г.Әпсәләмов

11) *күч.* Авырлыклардан, мәшәкатьләрдән, күңелне борчый торган нәрсәләрдән, авырлык-борчу тудырган кешеләрдән һ.б.ш. котылу, арыну. *Бандитлардан тынгач, Тора алмадым Дус шахтёрлар белән Уралда.* Н.Баян

**Тына бару** Әкренләп, әз-әзләп тыну. *Аяк табаны белән ул җирнең суына башлаганын, анда тамырлар хәрәкәтенең тына барганын тоя иде кебек.* М.Маликова. *Күк күкрәгән саен, диңгез тына бара, дулкыннар әкренләп басыла-басыла да, дөнья тып-тыныч булып кала.* Р.Вәлиев

**Тына башлау** Тынуга табан бару. *Хикмәттер, бүтәннәр дә кинәт юашланып, тына башладылар.* Ә.Баян. *Барыйның энесе Мансур шул елгы иде, соңрак, сугыш тына башлагач киткән иде дә чулак булып кайтты.* Г.Якупова

**Тына калу** *к.* **тынып калу**. *– Гөлләр белән соңгы очрашуыбыз түгел, иптәшләр, ул бездә җәй буе торачак, – дигәч, халык тына калды.* Г.Әпсәләмов

**Тына төшү** Тагын да тыну; бераз тыну. *Матур гына талашып килгән абыстайлар, без якынаю белән, тына төштеләр.* Һ.Такташ. *Ята торгач, бу давыл тына төште, ләкин дөньяда бүтән төрле тавышлар да җитәрлек икән бу якта!* А.Гыйләҗев

**Тынып алу** Аз гына вакытка тыну. *Беразга тынып алган буран янә котыра башлады.* Г.Галиев. *Ул да түгел, җил тынып алган мизгелләрдә яфраклар лепердәшүе, кошларның канат кагышы ишетелеп-ишетелеп калды.* Р.Мөхәммәдиев

**Тынып бару** Торган саен күбрәк тыну. *Гранит һәйкәл булып баскан шагыйрь тынып барган шәһәргә уйчан гына карап тора.* Г.Әпсәләмов. *Ни соң яткан авыл да инде тынып бара иде, чөнки таң белән тагы торасы бар.* Ф.Бәйрәмова

**Тынып бетү** Тәмам тыну, тулысынча тыну. *Төн уртасы җиткәч, барлык шау-шу тынып беткәч, кош-корт йокыга киткәч, Җамал әбигә тагы эш чыкты.* А.Алиш

**Тынып җиту** Тулысынча тыну. *Ләкин давыл әле бөтенләй үк тынып җитмәгән булып чыкты.* Н.Фәттах. *Күбесенең әле җаны да тынып җитмәгән, саңаклары әледән-әле сулык-сулык итеп куя.* Р.Батулла

**Тынып калу** Тынган хәлгә килү. *Я кинәт очынып-очынып китә, я көрсенеп тынып кала.* Ф.Яруллин. *Бу – бил алышыр алдыннан ике көрәшченең мәйдан уртасында кинәт кенә тынып калуы кебек иде.* М.Мәһдиев

**Тынып килү** Тынуга таба бару; тыну дәрәҗәсенә җитеп килү. *Ә бураннар инде тынып килә, Ә бураннар китә кышлардан.* Р.Сәлах. *Аннан, сугыш яңа тынып килгән Кавказда коралсыз да булмыйдыр.* Татарстан яшьләре

**Тынып тору** Вакытлыча тыну; билгеле бер вакытка тыну. *Бу араларда клуб ачылмады; каз өмәләре башланмаган; аулак өйләр дә тынып тора.* А.Гыйләҗев. *Халык бермәлне тынып торды.* А.Вергазов

**ТЫНЧУ** I *ф.* 1) Һава алмашынмау, җил исмәү сәбәпле саф һава, кислород бетү, исле, сасы, авыр һавалы хәлгә килү. *Ишектән керүгә, борыннарына тынчыган, күңелне болгандыра торган ис килеп бәрелде.* А.Алиш. *Наиләнең тычкан исе белән тынчыган салам эскерте төбендә укыган зәһәр хөкеме кылт итеп исенә төште.* А.Гыйләҗев

2) Сөрсү, куксү (су, һава тур.). *Кыш буенча тынчыган һавада бикләнеп торган шәкертләрнең авыру үпкәләренә Идел өстендәге язгы саф һава сөткә пешкән боткага атланмай килешкән төсле булды.* К.Тинчурин. *Ул бассейннардагы тынчыган суларны кем агызырга тиеш дип уйлыйсыз?* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Искерү, катып калу, артта калу, торгынлыкта булу. *Болай да сезнең тынчыган тормышыгызга бераз саф һава өрер өчен генә кайта идем.* Ф.Яруллин. *Күз алдымда тынчый дөнья – Кысыла күкрәкләр!* Р.Миңнуллин

**Тынчый бару** Торган саен тагын да тынчу. *Күл торган саен тынчый бара иде.* Сабантуй

**Тынчый башлау** Тынчырга тотыну. *Хәрәкәтсез ятып тынчый башлаган сазлык ул.* И.Низамов. *Торба чокырына тулган сулар җәйгә чыккач тынчый башлады.* Р.Рахман

**Тынчып бетү** Тәмам тынчу, бөтенләй тынчу. – *Фу, тынчып беткән икән бу! – дип, эткә ташладым.* Г.Ибраһимов. *Кайчандыр яшь кызлар, киленнәр йөзе чагылган коелар ләмләнеп, боткаланып, тынчып беткән.* Р.Фәйзуллин

**Тынчып тору** Билгеле вакыт дәвамында тынчу. *Казлар тынчып тормасын, Юып кайтыйк ять кенә.* Ф.Тарханова

**Тынчып яту** *сөйл.* Озак вакыт тынчу. *Урамда яз башланырга тора, ә син монда тынчып ятасың.* Г.Рәхим

**ТЫНЧУ** II *с.* 1) Саф һава, җил кермәү сәбәпле сөрсегән, сасыган. *Ни өн, ни төш түгел бит, дип утырасың шулай аңгы-миңге хәлдә тынчу вокзал бинасы эчендә.* М.Вәлиев. *Зөбәйдә бар көченә алдан чокып куйган такталарны этеп җибәрде, тынчу вагон эченә саф яз һавасы бәреп керде.* И.Сиражи

2) *күч.* Искергән, торгынлыкта калган; яңалыкны кабул итми торган; авыр. *Әдәбиятта ул заманнарда булган тынчу кысанлык комачаулагандыр, күрәсең.* Г.Сабитов. *Тынчу заман. Илдә эшсезләр юк, эшлексезләр генә калып бара.* А.Тимергалин

**ТЫНЧУЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **тынчу**. *Укытучылар шыплап тутырылган сыйныф бүлмәсе тынчуланырга өлгергән иде.* Ф.Яхин. *Шулай итеп, 1980 нче елларның соң чиккә җитеп тынчуланган, әшнәлек, ялагайлык, бары тик үзенә файдалы кешене генә санга сугу гадәтләре купшы чәчәк аткан заманда, Ибраһимның күңел яшәешен чын дуслар бизәде.* Р.Нуруллина

**Тынчулана бару** Торган саен ныграк тынчулану. *Торган саен һава тынчулана гына барса да, без кузгалырга ашыкмадык.* М.Вәлиев

**Тынчулана башлау** Тынчулану билгеләре сизелү. *Бүлмәдә һава тынчулана башлаган иде инде.* И.Нуруллин

**Тынчулана төшү** Тагын да тынчулану; бераз тынчулану. *Юеш ис күбрәк таралды, бүлмә һавасы тагы да тынчулана төште.* Г.Гобәй

**Тынчуланып бетү** Тәмам тынчулану. *Ул гүяки тау елгасы, хәтеренең кыяларына бәрелә-бәрелә, төпләрендә яткан, инде онытылганнан исәпләнелгән үпкә һәм рәнҗешнең кара ташларын кузгата, астындагы тынчуланып беткән ләмне болгата, тынгы белми иртә-кич, көндезен-төнен ага.* Ф.Яхин

**Тынчуланып китү** Соңгы арада тынчулану. *Мәчет эчендә һава тынчуланып китте, шулай булуга карамастан, Коръән китабыннан «Рәгъд» («Күк күкрәү») сүрәсен укуны дәвам иттем.* Өмет

**ТЫНЧУЛЫК** *и.* Тынчу булу үзенчәлеге. *Тынчулык үзенекен итте: атларыбызның касыклары тирләп чыкты, әчкелтем тир исе болай да тынчу һаваны тынчулап тирә-якка таралды.* Г.Галиев. *Шуңа да Совет чоры биналарында була торган тынчулык та, үтәли искән җил дә юк монда.* Л.Әбүдәрова

**ТЫНЧЫК** *с. к.* **тынчу** II. *Ул әйтә: «Сезнең Казаныгыз тынчык бер сазламыкка әверелгән».* Г.Рәхим

**ТЫНЧЫТУ** *ф.* 1) Исләндерү, сасыту; авыр һавалыга әйләндерү. *[Солтан], өйне тынчытмас өчен, тәмәке көйрәтергә ишек алдына чыккан.* А.Расих

2) Сыйфатын бозу, начарайту. *Заман сулышы тынчыта моңны...* Ф.Гыйззәтуллина

**Тынчыта башлау** Тынчытырга тотыну. *Бу ис бүлмәне тынчыта башлады.* Р.Вәлиева

**Тынчытып тору** Озак вакыт дәвамында тынчыту; даими тынчыту. *Аннары, әллә ни зур булмаса да, бөтен Яңа Бистәне сасы ис белән тынчытып торган заводның биек коймасы буеннан үтә дә Идел ярына чыга...* М.Хәсәнов

**ТЫНЫГУ** *ф. диал.* 1) Тукталу, басылу, тыну (табигать күренешләре тур.)

2) Ял итү, хәл җыю. *Бу юлы үзен ярыйсы гына тыныккан, көч җыйган итеп хис итте.* И.Хуҗин. *Төшләр күреп, тән тыныгып үткәрдем узган төнне.* Безнең гәҗит

**ТЫНЫК** *с. диал.* Тымызык, тын, тыныч. *Тынык Димдә толымнарын Юа тал иркәләнеп.* Җыр. *Тынык һава эчендә нечкә генә, пөхтә генә бер ислемай исе.* Г.Исхакый. *Төн тынык.* М.Мәһдиев

**ТЫНЫЧ** *с.* **1.** 1) Юк-барга борчылмый, дулкынланмый, ярсымый торган; сабыр, басынкы. *Муса да характеры белән тыныч кеше.* С.Хәким. *Әйбәт, тыныч кеше иде Байтимеров Газиз бабай.* Т.Миңнуллин

2) Шундый кешегә хас; эчке рухи тынычлыкны белдерә торган. *Ул нишләптер Сәгыйтькә карата үзендә баягы кебек дошманлык тойгысы сизмәде: студентның йөзе тыныч, эшчән иде, ул аннан һич тә көлергә дә уйламый иде бугай.* Н.Фәттах. – *Барыбер утынны алып кайтабыз, тик кулны пычратасы килми, – диде абыйсы, тыныч тавыш белән.* М.Мәһдиев

3) Тавыш-тынсыз, дустанә бара торган. *Римма тыныч сөйләшү, киңәшү рәвешендә зарланган кебек итеп әйтте.* Х.Камалов. *Әле генә бик тәмле, тыныч әңгәмә иде.* М.Мәһдиев

4) Ашыкмый торган; салмак, әкрен. *Хисмәт болдырдан тыныч адымнар белән, акрын-акрын, аяк бутамый гына төште.* Ф.Яхин

5) Башкаларны борчымый торган, башкаларга борчу-мәшәкать китерми торган. *Андый тыныч, әйбәт күршеләр бөтен кешегә дә тәтеми бит әле.* М.Вәлиев. – *Гади, тыныч балакаем, – ди әнисе дә, күз карашы белән генә булса да кызын сөеп-сыйпап.* Э.Закирова

6) Бернәрсә дә тынычсызламый, борчымый торган; мәшәкатьсез, борчуларсыз. *Мин сезгә әйтә килдем, тыныч чакта күчегез, дидем, – тыңламадыгыз.* Т.Гыйззәт. *Хыял күптән тыныч тормышны уйлап кинәнә дә бит.* Х.Камалов // Борчылуларсыз, төрле мәшәкатьләрсез башкарыла торган

7) Җилсез, һавасы тымызык булган. *Аннары Нәсимәнең торган фатиры да әллә ни ерак түгел ич: тыныч көнне матур гына кайтканда, егерме минутта өйдә булырлык ара.* М.Вәлиев. *Ул колакка сизгерлеген күрсәң: тыныч көндә кар яуганны да ишетә, билләһи менә, һич ялгансыз.* К.Кәримов

8) Хәрәкәтсез, селкенүсез; дулкынланмый торган. *Шул тыныч күлдә аккош белән каз яшәгәннәр.* А.Алиш

9) Шау-шусыз, тавышсыз, ыгы-зыгысыз. *Дөресен генә әйткәндә, һәр почмагыннан җылы бөркелеп торган якты, чиста, тыныч өйдә яшәве кызыктыра.* Л.Ихсанова. *Салмак кына атлап бара торгач, транспорт аз йөргән тыныч урамның тротуарына килеп чыктык.* К.Миңлебаев

10) Көч кулланмыйча, сугышсыз хәл ителә торган. *Бөек сәясәтче Ганди атлы шәхес Англия дип аталган колонизаторга буйсынмауның тыныч юлын тәкъдим итеп, үз дигәненә иреште.* Т.Миңнуллин

11) Сугышмый торган; сугышта турыдан-туры катнашмый торган. *Юк, үлемнән курыкмыйм мин, ләкин тыныч халыкка корал күтәрүдән куркам.* Ф.Яруллин. *Латвиядә хезмәт итүче хәрбиләрнең беренче тапкыр тыныч халыкка ярдәм сорап мөрәҗәгать итүе иде.* З.Зәйнуллин

12) Сугышсыз; бернинди сугыш алып барылмый торган; хәрби булмаган. *Сугыштан соңгы тәүге тыныч ел.* З.Мәхмүди

13) Тынычлык шартларында, сугышсыз вакытта башкарыла, алып барыла торган. *Бу күкрәү аларны киң кырларга, тыныч хезмәткә чакыра, туган җирләрен сагындыра, ашыктыра, җилкендерә.* Г.Әпсәләмов. *Хәрби хезмәттә дә, тыныч төзелештә дә тапшырылган эшкә үтә җаваплы караучы Заһидуллин Гыйльмулланың үткән сугышчан юллары истәлекле.* Т.Нәҗмиев

14) Тыныч максатларны күздә тоткан, коралсыз. *Хөкүмәт Петроградтагы тыныч демонстрацияне аттырды!* И.Гази

15) Тынычлык сәясәте алып бара торган; тынычлык шартларында яши торган. *Тыныч илебезгә юлбасарларча һөҗүм ясаган кыргый фашистларга каршы Ватаныбызның күтәрелүен оныту кыен, сөеклеләрем.* Г.Кутуй. *Республиканың тыныч көнкүрешенә бернинди куркыныч янамавына инангач кына бизнесменнар сөйләшүгә баралар.* М.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Дулкынланмыйча, ярсымыйча, сабырлык белән. *Монда татыган шатлыгымны мин хәзер тыныч яза алмыйм.* Г.Кутуй. – *Тракторны тик торгызып булмый ич инде, – диде Һарун тыныч кына.* Н.Фәттах

2) Тавыш күтәрмичә, кызмыйча, дусларча. *Ягез инде, тыныч кына сөйләргә тырышыгыз.* Г.Каюмов. *Гадәттә үзен тыныч тоткан Гөлкәйнең кыланышларында чыннан да ниндидер үзгәреш сизелә иде.* Х.Ширмән

3) Тигез, салмак, ашыкмыйча. *Әнә шуңа күрә алар бик тигез ритм белән икәүләп тыныч кына җырлап утыралар: «Мәк чәчәген өздем ялгыш кына...»* М.Мәһдиев. *Ана баланың тыныч мыслаган борынына, йомык күзләренә, йокы аралаш имгәндәй мимылдаган авызына карады да елмаеп җибәрде.* М.Маликова

4) Борчымыйча, тынычсызламыйча. *Син дошманны тыныч яткырмадың, Нәләтләп һәм ачып этлеген.* М.Җәлил

5) Борчылмыйча, тынычсызланмыйча, курыкмыйча. *Мәктәптә тыныч эшләргә теләсәң, җәбер-золым күрәсең килмәсә, директор хатынының күңеннән тор.* М.Мәһдиев. *Сәбиләнең, аз гына да исе китмичә, һаман шулай кухняда тыныч кына әвәрә килүенә аптырап, кая сугылырга белмичә, әле тәрәзә каршына барды, әле күлмәк якаларын бер эләктереп, бер ычкындырды.* Ф.Яруллин

6) Хәрәкәтсез; хәрәкәтләнмичә. *Ләкин теге кеше, аның хәлен күреп, тыныч кына ятарга куша, кесәсеннән чүпрәккә төргән икмәк кисәге чыгара да, урталай бүлеп, яртысын Хафизовка бирә.* Р.Мостафин. *Ашкына, тыныч кына басып та тора алмый.* М.Әмирханов

7) Тавышланмыйча; тавышсыз, дәшми-тынмый. *Кымшанмыйча да тыныч кына утырган дустым ниләр мәтәштерергә җыена икән?* К.Миңлебаев. *Сөендек көтмәгәндә ике йодрыгы белән өстәлгә шап итеп сукты, теге бүлмәдә тыныч кына яткан эт, бу тавышка лүрт-лүрт йөгереп кереп, Алевтина Петровнаның бот араларында урала башлады...* А.Хәлим

8) *күч.* Бернинди каршылыксыз, үз җае белән. *Икенчеләренең холкында артык үзгәреш сизелмәде, алар, коллективка тиз генә кушылып, тыныч кына укый башладылар.* Л.Ихсанова. *Тормышы авыл юлына көйләнгән арбадай тыныч кына келтерәп тәгәрәгәндә, көтелмәгән бер вакыйга аның рухи дөньясын челпәрәмә китерде.* Т.Галиуллин

9) Сугышмыйча, тату. *Ишегалдында тырманып тыныч кына йөргән кызыл әтәч, титибикәләрен ияртеп, абзарга ук кереп китә.* Н.Әхмәдиев. *Син җир йөзендәге барлык халыклар белән дә тыныч һәм тату яши беләсең.* Т.Миңнуллин

**3.** *и. сир. к.* **тынычлык** (*6 мәгъ.*). *Без мәскәүлеләргә тимәбез, алар да безне тынычта калдырсыннар, ди Сөембикә.* Х.Камалов. *Кеше аңында пыскып яткан үлемнән курку, җил-давыллардан, афәтләрдән читтәрәк калып, «иярсез алаша» кебек, тынычта яшәү теләгән «төртеп» чыгара, исән-имин калу хыялы хәйлә, мәкер юлына этәрә.* Т.Галиуллин

◊ **Тыныч аяк белән кайту** Бәлаказасыз, хәвеф-хәтәрсез кайту. *Сине үз балам кебек күрүче идем. Инде тыныч аяк белән кайткан булсаң иде.* Г.Ибраһимов. **Тыныч вөҗдан белән** *к.* **тыныч күңел белән**. *Үзегезгә дә тыныч вөҗдан белән дөнья куярга язсын.* Ә.Баян. **Тыныч карый алмау** 1) Кемгә дә булса гашыйк булу, мәхәббәт тоту. *[Газинур] Сәлимнең Миңнурыйга тыныч карый алмаганлыгын белә.* Г.Әпсәләмов; 2) Нинди дә булса мәсьәләгә, эшкә, күренешкә һ.б. карата кызыксыну күрсәтү; битараф булмау; ошату. – *Бәлки, Ленинград кешесе булганга, мин ак төннәргә шулай тыныч карый алмый торганмындыр, – дип, Саша сүзен дәвам иттерә.* Г.Әпсәләмов. *Шуннан бирле мин төрле статуэткаларга, скульптурага һәм гомумән рәсемгә тыныч карый алмыйм...* А.Тимергалин; 3) Ярсу, ачу чыгу. *Ләкин әнә шул ике сакчы, ике терәк, һичничек бер-берсенә тыныч карый алмыйлар, һичшиксез конфликтка керәләр.* М.Мәһдиев. **Тыныч күңел белән** Вөҗдан газабы кичермичә,

борчылмыйча, үзенең хаклыгына ышанып, саф күңел белән. *Димәк, тормыштан тыныч күңел белән китәргә мөмкин.* С.Хәким. *Тыныч күңел белән китә ала хәзер Хәлим.* Г.Гыйльманов

**ТЫНЫЧЛАНДЫРГЫЧ** *с.* **1.** Тынычландыра, ярсуны баса торган; тынычлык китерә, тынычлык бирә торган. *Нажия кызын юатуның файдасыз икәнен аңлап, аңа тынычландыргыч дарулар бирде дә өенннән чыгып китте.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ. махс.* 1) Үлчәү җиһазларында укны тирбәлүдән туктату җайланмасы; демпфер. *Электромагнит тынычландыргыч*

2) Ярсуны баса торган дәвалау чарасы. *Шулай ук әлеге дару – яхшы тынычландыргыч һәм йоклаткыч та.* Шәһри Казан

3) *күч.* Күңелгә рәхәтлек бирә, юата, мавыктыра торган нәрсә. *Аңа да шундый тынычландыргыч кирәк.* Сөембикә

**3**. *рәв. мәгъ.* Тынычландырырлык итеп. *Матур тавыш белән укылган дога балаларга тынычландыргыч тәэсир итте.* Ф.Яруллин. *Үләннең сыек экстракты кан басымы күтәрелү белән бәйле авыруның башлангыч чорында артериаль кан басымын төшерә һәм организмга тынычландыргыч тәэсир итә.* Агулы үсемлекләр

**ТЫНЫЧЛАНДЫРУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тынычлану**. *Гөлүсә тагын елмайгандай итте, тагын Газины тынычландырды.* М.Хәсәнов. *«Йөзем ак, күңелем пакь» дип, үзен тынычландырырга тырышса да, барып чыкмады.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Баш күтәргән халыкны буйсындыру, сәяси чуалышларны бастыру. *Шулвакыт Кара Чыршылар арбасы өстенә Тимерхан менеп басты. Аның тамагы карлыккан иде – халыкны чак тынычландырды.* М.Мәһдиев. *Вәкил, халыкны тынычландырып, сүзен дәвам итте: – 1950 елда Корея – Америка сугышы башланды.* Р.Зарипов

**Тынычландыра бару** Торган саен тагын да тынычландыру. *Урамның шушы гадәти ыгы-зыгысы Сабадырёвны да күпмедер тынычландыра бара иде.* З.Фәтхетдинов

**Тынычландыра башлау** Тынычландырырга керешү, әкренләп тынычландыру. *Сестралар җыелды һәм аны чолгап алып тынычландыра башладылар.* Х.Камалов. *Йөгереп килгән уңайга Майя Хәлим кулыннан баласын йолкып алды, аннары, аңа артын куеп, чын аналарча сөйләнә-сөйләнә, һаман елаудан туктый алмаган сабыйны тынычландыра башлады.* Г.Гыйльманов

**Тынычландыра килү** Күптәннән бирле тынычландыру. *Александр Иванович бу җыелышларда нindidер ясалмалык сизсә дә, «яхшылыктан яманлык эзләмиләр» дигән тыйнак фикер белән үзен тынычландыра килде.* Ә.Баян

**Тынычландыра тору** Әледән-әле тынычландыру; берәр эш-хәлгә кадәр тынычландыру. *Сафиулла урыннан кузгала, сүз тугылата башласа, тизрәк тынычландыра торды.* Ф.Яхин. *Без, киресенчә, әни монысы өчен генә борчылмаса ярар иде дип, аны тынычландыра тора идек.* Безнең гәҗит

**Тынычландыра төшү** Тагын да тынычландыру; бераз тынычландыру. *«Яшен башта Алмыш хан өен сугарга тиеш», – дигән уй Тотышны бераз тынычландыра төште.* Н.Фәттах. *Янәшәсендә тере кеше барлыгын тою аны бары тынычландыра төшә иде.* Д.Бүләков

**Тынычландырып алу** Тиз генә тынычландыру; бераз тынычландыру. *Шундук: «Соңрак, җаен туры китереп, бер сораштырырмын әле», – дип, үз-үзен тынычландырып та ала.* М.Хәсәнов. *Маһруй, ирләр сүзенә кушылырга җөрьәт итмәсә дә, атасы белән малаеның артык кызып китеп, чамадан ашмауларына күз-колак булып тора, әле берсенә, әле икенчесенә карап, күз карашы белән тынычландырып ала иде.* Р.Вәлиев

**Тынычландырып бетерү** Тәмам тынычландыру; тулысынча тынычландыру. *Аны тынычландырып бетерүем булды, стюардесса: – Һава шартлары начар булу сәбәпле, самолёт Бөгелмәгә төшә алмый, шуңа күрә кире Казанга кайтабыз, – диеп котыбызны алды.* Н.Әхмәдиев

**Тынычландырып җибәрү** Сизелерлек тынычландыру; бераз тынычландыру. *Аның бармаклары салкынча һәм назлы иде, аларның орынуы тынычландырып җибәргәндәй итте.* М.Маликова

**Тынычландырып йөрү** Һәрвакыт, гел тынычландыру, билгеле бер вакыт тынычландыру. *Мин шулай әтинең боерыкларын үтәп, аны тынычландырып йөрим төн буе.* Ф.Тарханова. *Минем белән бергә килгән яшь укытучыларның дәрестән еш кына елап чыкканы да, уку-укыту эшләре буенча мөдирнең балалар белән бергә яшь мөгаллимнәрне тынычландырып йөрүе дә хәтердә калган.* Ә.Исхаков

**Тынычландырып карау** Тынычландырырга тырышу, тынычландырырга омтылу. *Председательлек иткән баш инженер Галинуров тынычландырып карады, ләкин ул тәмам ярсыган иде.* Д.Бүләков

**Тынычландырып килү** Озак вакыт дәвамында тынычландыру; күптәннән тынычландыру. *Бәби тапкач бөтенесе җайланыр дип, үзен тынычландыра килде.* Ф.Яруллин. *Фатыйма бер пансионатта яшәгән, хәзер ул ябылган, дип, әниләрен дә, авыл халкын да тынычландырып килде.* Ф.Садриев

**Тынычландырып кую** Тиз арада яки алдан тынычланган хәлгә китерү. *«Яңалыклар»да бер канал кайдадыр самолёт егылып төшүне хәбәр итсә, икенчесе: «Җинаять эше ачылды», – дип, борчылуга төшкән агай-энене тынычландырып куя.* Ә.Зарипов. *– Кәгазьләрегез тәртиптә булса, беркем бәйләнә алмас, – дип, Хәлил ханымны тынычландырып куйды ---.* Т.Галиуллин

**Тынычландырып тору** Даими тынычландыру, гел тынычландыру; беразга, вакытлыча тынычландыру. *Өмет дигәне генә тынычландырып тора күңелне, ә ул миндә көннән-көн кими бара.* Э.Яһүдин. *Тик берни эшләп тә булмый, ярый әле җылы сүзләр әйтеп тынычландырып торучы Айгөле бар.* Р.Сәгъди

**ТЫНЫЧЛАНДЫРУ** II *и.* Курку, борчылу, дулкынлану, ярсу һ.б.ш. хисләрне бастыру процессы. *Ә ул вакыйгалар, бара-килә, ул язучы әфәндебезне журналның редколлегия әгъзасы итеп*

*сайлап тынычландыру белән тәмамландылар...* Ф.Яхин. *Без аларны тынычландыру белән шөгыльләнәбез дә инде.* Ватаным Татарстан

**ТЫНЫЧЛАНУ** *ф.* 1) Һәртөрле хәрәкәтләр (дулкынлану, җил исү, селкенү һ.б.ш.) тукталу, басылу. *Алар давыл тынычлануга ук юлга кузгалдылар.* М.Мәһдиев. *Тирә-як тынычлангач, су җылынгач йөзәргә ярата Һәдия елгада.* Г.Якупова

2) Ыгы-зыгы кылүдән, шау-шудан, сөйләшүләрдән туктау. *Дим, «зал»ның тынычланганын бераз көтеп, чын артистларча бик ягымлы тавыш белән сузып җибәрде: «Без – җиңелмәс данлы ил батыры, һич какшамас безнең изге антыбыз...»* Г.Әпсәләмов. *Рушад, үзен тыныч тотарга тырышып, болай диде: – Сез тынычланмый торып, мин дәресне башламыйм.* М.Мәһдиев

3) Курку, борчылу, дулкынлану, ярсу, дәртләнү һ.б.ш. хисләр басылу; тыныч халәткә килү, үз-үзен тыныч тота башлау. *Биниһая авыр чакларда да гел шулай тынычлана идем, барын да үзем теләп, алдан белеп тордым лабаса, бирәү дә көчләмәде, түзәргә кирәк, ди торган идем.* К.Тимбикова. *Аның әле ныклап торып тынычланасы килде, чәчелгән, таркалган уйларын, хис-тойгыларын барлыйсы, тәртипкә саласы килде.* Н.Фәттах

4) Борчылудан, дулкынланудан, ярсудан туктау (йөрәк, күңел, җан тур.). *Шуннан соң, икәвенең дә күңелкәйләре тынычлана, бер-берсенә якынлык тоела, хөрмәт хисе тагын да арта.* К.Миңлебаев. *Тәне ничек тә үз калыбына кайтыр, җаны да тынычланыр; зиһене генә иләсләнеп китмәсен, ул ялгышса, баш бетте дигән сүз.* Г.Гыйльманов

5) Төрле чуалышлар, тәртипсезлекләр басылу, туктау. *Аннан соң җәмгыять тынычланды, һәм татар иҗтимагый үзгеге дә тынычланды.* Д.Исхаков. *Инде халкың да тынычланды, басылды, имин илдә яшәп ятабыз...* Г.Каюмов

6) Тынычлык (*6, 7 мәгъ.*) урнашу. *Боерган булса, дөньялар гына тынычлансын.* Л.Ихсанова. *Бу юл «дөнья тынычлыгы өчен дә», «безнең кеби көчләнгән милләтләрнең тынычланып, мәдәният вә чәчәк ату юлларына аяк басуларына да бердәнбер чарадыр».* Х.Миңнегулов

7) *күч.* Булган, ирешелгәннәр белән канәгатьләнү. *Ирешелгәннәр белән генә тынычланып, тукталып калырга һич тә исәбе юк әле аның.* Л.Шагыйрьҗан. *Хатын-кыз дигәнең җавапсыз калган сорауларны бик өнәп бетерми, җавап тапмый торып тынычланыр дип уйлама да.* К.Кәримов

**Тынычлана бару** Әкренләп, әзлекле рәвештә тынычлану. *Яңгыр астында басып торган саен, ул үзенең тынычлана барганын тойды, әле генә күңелендә баш калкытып куйган уйлар юкка чыкты.* Р.Вәлиев

**Тынычлана башлау** Тынычлануга таба бару. *Хәбәре килгәч кенә, бераз тынычлана башладым.* К.Миңлебаев. *Никитич бераз тынычлана башлады, тавышы тигезләнде.* Х.Камалов

**Тынычлана төшү** Тагын да тынычлану; бераз тынычлану. *Котан тынычлана төшкәч, бикә кулын тартып алды.* Н.Фәттах. *Бераз тынычлана төшкәч, ул: «Ыгы-ыгы, исемем Нәфисә», – дип әйтә алды.* Ф.Яруллин

**Тынычланып бетү** Тәмам тынычлану, бөтенләй тынычлану. *Әмма тынычланып бетмәгән, ярсуы кимеп өлгермәгән язгы су аны кирәкмәгән якка аска таба өстери.* Ә.Баян. *Инде тынычланып бетә язган кара айгырны җитәкләп, Волхов елгасы ягына китеп барды.* З.Зәйнуллин

**Тынычланып җитү** *к.* **тынычланып бетү**. *Әмма Ык тынычланып җитмәгән иде әле.* Г.Сабитов. *Ләкин әнә бөтенләй үк тынычланып җитмәгән икән, йөрәгендә әле һаман төен торып калган икән, һәм менә ул хәзер яңадан да дуларга чамалый иде, ахрысы.* Н.Фәттах

**Тынычланып калу** Нindидер бер вакыйга һ.б.ш.дан яки берникадәр вакыт узгач тынычланган хәлгә килү. *Шуңа күрә дә ул, «кеше үз көче белән дә тормышка тиенергә мөмкин» дигән сүзен исбат иткәннән соң, тынып, тынычланып калды.* М.Хәсәнов. *Бүген һич уйламаганда ул сабырланып, тынычланып калды, гәүдәсенә кыз чагы җиңеллеге, күңеленә тигезлек кайтты.* А.Гыйләҗев

**Тынычланып килү** Әкренләп, азазлап тынычлану; тынычлануга таба бару. *Моңа мәскәүнекеләр шартлап үлә язды, әле яңа тынычланып киләләр.* Н.Әхмәдиев. *Иң мөһиме, халык тынычланып килә, хезмәткә кайта.* Ф.Сафин

**Тынычланып китү** Нindидер сәбәптән тынычлану. *Шулай да тиз генә тынычланып китә алмады ул.* Л.Ихсанова. *Йорт башының төпле киңәшеннән соң һәркайсы тынычланып киткәндәй булды.* Р.Низамиев

**ТЫНЫЧЛАП** *рәв.* Иркенләп, борчылмыйча, тыныч күңел белән, тыныч вакытта, тынычланып. *Тынычлап эшлә, дип, минекеләр өйгә кайтып киттеләр, син дә китәрсең, дидем бит, әй!* К.Миңлебаев. *Кичке ашын бик тынычлап, тәмләп ашаганнан соң, тәмам байларча кыяфәттә урамга чыгып барышлый гына алды ул үзенә килгән хатны.* М.Вәлиев

**ТЫНЫЧЛАТУ** *ф. диал. к.* **тынычландыру**. *Карт ашыкмады, бияне тынычлатып, ялыннан, сыртыннан сыйпап, тагы җиленгә кул сузды.* Г.Ибраһимов. *Һәрхәлдә, мин шушы яңа әйберемне язып бетереп, ул халык тарафыннан танылмыйча торып, үземне тынычлата алмаячакмын.* Г.Бәширов

**ТЫНЫЧЛА́У** *ф.* 1) *к.* **тынычлану**. *Тынычлый аның йөрәк, Сусавын була баскандай, Савыга өзек үзәк.* Ф.Яхин

2) Берәр кешене яки хайванны ярсуыннан, шаулавыннан һ.б.ш. туктату; тынычландыру. *Нәгыймь аны тынычларга теләп дәште: «Я, төкер әле, Сәфәр, куй әле дөнья сүзен!»* Ә.Фәйзи. *Исерек төн тынычлый җанымны, Төнгә керәм, төндә йөрим мин ---.* Р.Сабиров

**Тынычлап калу** Нindидер вакыйгадан, хәлдән һ.б.ш. соң тынычлау. *Аңар бирдем азатлык мин, үзем дә шул вакыт күрдем: Тынычлап калды никтер һәм тәмам иркенләде күңлем...* Г.Тукай. *Мәсрүрә китте, Гөлчирә тынычлап калды һәм укыту эшләренә катнаша башлады.* М.Мәһдиев

**Тынычлап китү** Сизелерлек, күзгә күренеп тынычлау. *Ул килгәч, Хәсән абый берникадәр тынычлап киткәндәй булып сузылып ятты.* Көндәлек язмалар

**Тынычлап кую** Тиз арада тынычлаган хәлгә килү. *Әле генә үлем турында уйлап курыккан карт тынычлап куйды: әле, боерган булса, җир өстендәге башка кешеләр кебек кичерәсе бер мәшәкать булыр бу.* М.Мәһдиев

**Тынычлап тору** Билгеле бер вакытка тынычлау; вакытлыча, беразга гына тынычлау. *Бер шул ярминкәләргә киткән чагында гына бераз тынычлап торасың.* Г.Камал. *Кечерәк өй зурлыгындагы аклы-зәңгәрле бозларның берберсенә бәрелеп, таралып төшүен, шундый ук мәһабәт бозларның бер минутка гына тынычлап торган су тигезлеген ватып-җимереп калкып чыгуын, күккә ашырга теләп тә, егәрләре бетеп, шапылдап суга килеп төшүен карап тору кызык та, шомлы да иде.* Г.Гыйльманов

**Тынычлый башлау** Тынычлауга табан үзгәрү. *Губертны нәкъ менә хәзер, Бөгелмәдә алган тәэсирләре суынганчы, күңеле тынычлый башлаганчы күрәсе килә иде аның.* Ж.Рәхимов

**ТЫНЫЧЛЫК** *и.* 1) Бернинди шаушу, ыгы-зыгы, хәрәкәт булмау; тынлык. *Ә тирә-якта шундый тынлык, шундый тынычлык, әйтерсең табигать бик каты тартыштан соң арыган да хәзер, әкрен генә сулыш алып, хәл җыя.* Г.Әпсәләмов. *Шулай да инде көн сүрелгән, кичке һавада тынлык һәм тынычлык урнашкан иде.* Н.Фәттах

2) *физ.* Хәрәкәтсезлек, тикторыш халәте. *Тынычлык хәленнән хәрәкәткә күчү*

3) Кешенең яки хайванның үз-үзен сабыр, тыныч тотышы. *Яшь офицер хөкемнең карар кәгазен укыганда да тоткынның йөзе коелган таш кебек катып торуы аның бу тынычлыгын тагы көчәйтте.* Г.Ибраһимов. *Биясе йөрсен, тынычлыгын бозмыйк, тиздән уйнак колын алып кайтыр, шулай боерган булыр, дим.* М.Хуҗин

4) Рухи яки физик яктан борчылусыз, дулкынланусыз, тыныч халәт. *Күңелдә, психикада иминлек, тынычлык кирәк бит.* Ш.Галиев. *Йөзендә дә гамьсезлек, туклык, күңел тынычлыгы чагыла.* М.Маликова

5) Эшсез, мәшәкатьсез вакыт; ял. *Аннары киная белән өстәп куйды: «Гөлүсәгә тынычлык кирәк».* Г.Сабитов. *Арыган-йончыган тән үзенә ял, тынычлык сорый.* Р.Габделхакова

6) Бернинди дә чуалышлар, тәртипсезлекләр, хәвеф-хәтәр булмау; тәртип хөкем сөрү; иминлек. *Минем тырышлык аркасында изге Болгар илендә һәрвакыт тынычлык, иминлек булды.* Н.Фәттах. *Скифлар иленә тынычлык, муллык иңгәнче, кулыбыздан килгәнчә азык-төлек, кием-салымнар белән дә ярдәм итеп торырбыз.* Р.Сәгъди

7) Дәүләтләр арасында сугыш булмау; дәүләтләр, халыклар үзара тату, тыныч яшәү хәле. *Анысы шулай инде, сугыш барганда, чын тынычлык буламыни ул?* Ә.Еники. *Әмма Казан тынычлык турында килешү белән чыга, һәм чираттагы сугыш башланмыйча кала.* Т.Кәримов

◊ **Тынычлыгын алу** Тынычсызлау, борчуга салу, эчен пошыру. *Көтсә дә, бу хәбәр аның тынычлыгын алды.* Н.Әхмәдиев. *Васимә әби башлаган сүз Хәлимнең тынычлыгын алды.* Г.Гыйльманов. **Тынычлык бирмәү** Туктаусыз борчып, бимазалап тору, йөдәтү, интектерү, аптырату. *[Егет] бик уңган, тырыш булып чыкты, кая куйсаң да, кулыннан эш килгәнлеген күрсәтте, үзе янды, башкаларны яндыра белде, эленке-салынкы йөрүчеләргә тынычлык бирмәде.* Ә.Еники. *Аннары, табигате шундый булгангамы, кимсетелгән ирлек мин-минлеге тынычлык бирмәгәнгәме, күргән саен Гөлшәһидәгә берәр зәһәр сүз әйтмичә уза алмый башлады.* Г.Әпсәләмов. **Тынычлыкта калдыру** Кемне дә булса борчып, бимазалап торудан, йөдәтүдән туктау. *Утенечем бер генә: туган энеләремне тынычлыкта калдырсагыз иде, аларның бер гаебе дә юк, үзең беләсең, ыруыбыз – зур ыру безнең.* М.Әмирханов. **Тынычлык тапмау** Борчылу, тынычсызлану, хәвефләнү. *Хаклык булмаса, кешенең җаны урынында булмый, үзенә тынычлык таба алмый.* Х.Камалов. *Шушы хатны ертып ташлау белән генә, ул үзенә тынычлык таптымы соң?* А.Вергазов

**ТЫНЫЧСЫЗ** *с.* **1.** 1) Мәшәкатьле, һәртөрле борчу, ыгы-зыгы, шау-шу белән тулган. *Байтак көннәр, байтак төннәр, шомлы, йокысыз, тынычсыз төннәр үтәләр...* И.Туктаров. *Яңадан тынычсыз тормыш – авылдагыга караганда да газаплырак, авыррак тормыш башланды.* Н.Фәттах

2) Давыллы, шашкын, кызу хәрәкәттә булган, ярсу; болытлы, караңгы (табигать күренешләре тур.). *– Ява бу, явачак, – диде иптәш Бикчурин, кара болытлар белән капланган тынычсыз күккә карап.* Н.Фәттах. *Аларны тынычсыз диңгез каршы алды.* М.Вәлиев

3) Күңел тынычлыгы булмаган, борчулы (кеше, күңел, җан, йөрәк тур.). *Күңеле тынычсыз, җаны әрнүле Мансурның, чөнки балалары аннан көннән-көн читләшә баралар.* Г.Галиев. *Алсуның бөтен булмышы тынычсыз, аптыраулы, бу миңа авыр тәэсир итә.* М.Кәбиров

4) Күңелне борчый торган; тәшвишле (уй тур.). *Әмма күкрәген тынычсыз уй сыдырып үтте: «Нәрсә алып кайтырмын икән соң?»* Р.Зарипов

5) Тынычлыгы булмаган, куркыныч, шомлы (җирлек, урын, йорт һ.б. тур.). *Болар өйгә кергәч, Гөлнәзек йокыдан уянган кебек булып киерелде-сузылды да: – Ай-һай, дию дус, өең бик тынычсыз икән.* К.Насыйри. *Бу нинди тынычсыз урын?* Г.Тарханова

6) Башкаларга да, үзенә дә тынычлык бирми, бимазалап, аптыратып тора торган, тынгысыз (кеше тур.). *Әлбәттә, аны берәү дә шәл бәйләргә мәҗбүр итмәде, аңа эш кушмадылар, ләкин карчыкның йөрәге шундый иде, тынычсыз, тасырдык иде.* З.Хөснияр

7) Саташулы, бүленүле (йокы тур.). *Иптәшләрем, ярым утырган килеш, үзара сыенышып, каты, ләкин тынычсыз йокы белән, әледән-әле кыбырсып һәм мыгырданып йоклыйлар.* Р.Мостафин

8) Көйсез, елак (бала тур.). *Тынычсыз бала түгел иде ул, әниләренә бер-*

*нинди борчу-мәшәкать тә китермәде.* Р.Вәлиева. *Зифа бик тынычсыз, гел кулда гына күтәреп йөрергә туры килә аны.* Сөембикә

9) Җәмгыятьтәге тәртипләр, фикерләр белән риза булмаган, тормышта яңалык тели, эзли-эзләнә торган. *Ләкин еллар мине тынычсыз булырга өйрәттеләр.* Х.Туфан. *Җир турындагы документларны шундый оста итеп юкка чыгарган җирле хакимияттән үрнәк алыптыр инде, мөфти дә Әбдерәшитов кебек актив, тынычсыз кешеләрдән аларны юкка чыгару юлы белән котылырга уйлый.* М.Гайнетдинов

10) Тәртипсезлекләр, ризасызлыклар, һәртөрле чуалышлар булган. *Ә бүгенге көндә без тынычсыз заманда яшибез; адәм затын гөрелте-гүләүләр, шартлаулар, мең төрле җыр-музыка яңгырашы чолгап алган.* М.Галиев. *Европага һөҗүмен туктатып торып һәм кире кайтып, Батый, алга таба буйсындырылган рус җирләрен Идел буенда тиз арада барлыкка килгән Алтын Урда дәүләте составына кушудан баш тартып, тынычсыз, һәрвакыт болганып торган Болгарда үзенең вакытлы ставкасына нигез сала.* Т.Кәримов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Борчулы, тәшвишле; тик тормыйча, тынычланмыйча. *Чуарбикә нигәдер үзен тынычсыз тота иде.* М.Әмирханов. *Фаягөл төнне тынычсыз уздырды.* А.Әхмәтгалиева

2) Борчылып, мәшәкатьләнеп, бимазаланып, тыныч булмыйча. *Күрәсең, бу хезмәтченең үлеме хәлләрнең куерып җиткән вакытына туры килгәндер, ул төнне авыл бик тынычсыз уздырды.* Г.Бәширов. *Моңа кадәр ни дәрәҗәдә тынычсыз яшәгән булса, зур шәһәр тормышының сагынылган стихиясендә һәм бихисап мөмкинлекләр алдында шуның хәтле бәхетле сыман иде ул.* М.Вәлиев

3) Саташып, бүленә-бүленә (йокы тур.). *Тынычсыз йоклый хатының.* Л.Зөлкарнәй. *– Балам, бүген бигрәк тынычсыз йокладың, иртәгә иртәрәк ятарга тырыш, – дип кенә әйтергә теләгән иде ул үзе.* Сөембикә

**ТЫНЫЧСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Хәрәкәтләнү, тик тормау. *Кара бия, тынычсызланып, койрыгын селтәштереп куя, башын борып, әледән-әле безнең якка күз ташлап ала.* Н.Фәттах // Нәрсә дә булса борчу сәбәпле яки эчке кичерешләрнең чагылышы буларак, бертуктаусыз кул-тән һ.б. хәрәкәтләре ясау, тик тора алмау. *Бала тынычсызланган кебек боргалана, нидер көтә сыман.* М.Хәбибуллин

2) Ыгы-зыгы килү, шау-шу килү, тәртипсезләнү. *Карарга кирәк, кортлар тынычсызланмыймы, йорт-каралты ни хәлдә?* Г.Якупова

3) *биол.* Тере организм яки аның аерым әгъзалары тышкы ярсыткыч тәэсиренә бирелү. *Агулану башында нерв тынычсызлану билгеләре (күз бәбәкләре зураю, ярсу яки, киресенчә, боегу, аякның хәле киту яки гомуми хәлсезлек, йөрәк эшчәнлеге бозылу) күзәтелә ---.* Агулы үсемлекләр

4) Берәр нәрсәгә борчылу, дулкынлану, хәвефләнү, тәшвишләнү. *Минем хакта һичбер тынычсызланма, бәгърем, синнән аерылган минутларымны эшкә күмелеп уздырдым.* Һ.Такташ. *Тора-бара ул тынычсызлана, вакытывакыты белән аякларын бер-берсенә бәргәли, кулларын шапылдатып куя башлады.* Р.Вәлиев

**Тынычсызлана бару** Торган саен ныграк тынычсызлану. *Сәгатьтәнсәгать авыл тынычсызлана барды, кайнады, шаулады.* К.Тинчурин. *Аның саен әнисе Камилә апа тынычсызлана барды, гүя баланы эссе табага бастырып тотарга әзер иде.* Ф.Яхин

**Тынычсызлана башлау** Тынычсызланырга тотыну. *Кешеләрнең күңелләре төшите, һәркем үртәлә, тынычсызлана башлады.* Н.Фәттах. *Син борчылгач, бәләкәчебез тынычсызлана башлар.* Ф.Яруллин

**Тынычсызлана төшү** Элеккегә караганда да күбрәк тынычсызлану; бераз тынычсызлану. *– Нәрсә, мин әтинең шофёрын танымыйммы әллә? – диде кыз, тынычсызлана төшеп. – Чыннан да Ринат иде ул.* Ә.Сафиуллин. *Ләкин шундук, тынычсызлана төшеп, ирексездән куллары белән кесәсен капшарга керешә: күзлеген эзләде.* Р.Мөхәммәдиев

**Тынычсызланып алу** Аз гына, кыска вакыт кына тынычсызлану. *Муллалар килеп кергәч, бераз тынычсызланып алдылар.* Ф.Яруллин. *Бүлмәдәгеләр тагын тынычсызланып алдылар.* Ф.Садриев

**Тынычсызланып китү** Кинәт, нindидер сәбәпләр аркасында тынычсызга әйләнү. *Шулай матур гына көн итеп ятканда, дөньялар тынычсызланып китә.* Т.Биктимирова. *Шуннан төше хәтеренә килеп төшә дә, күңеле тынычсызланып китә: аның бер генә дә кар кешесе кулыннан үләсе килми...* Ә.Әминев

**Тынычсызланып куюу** Кинәт яки аз гына тынычсызлану. *«Кадерлем» сүзен ишетеп, мин тагын тынычсызланып куйдым.* Н.Фәттах. *Ишектән йончыган, кәефсез кешеләр килеп чыккан саен, ул кабат тынычсызланып куйды.* Ф.Җамалетдинова

**Тынычсызланып тору** Даими тынычсызлану; сөйләү моментында тынычсызлану. *Болай күңелләр тынычсызланып торганчы барып кайтсагыз яхшы булыр иде булуын.* Г.Камал. *Соңгы көннәрдә күңеле тынычсызланып торганга, сөйләшсәм-аралашсам әзрәк басылмасмы дип, Әкълимә эшеннән соң туры ахирәте Мәүсиләгә барган иде, өйдә булып чыкмады.* Ә.Әминев

**ТЫНЫЧСЫЗЛАНУЧАНЛЫК** *и. биол.* Тере организмның тышкы ярсыткычлар (чәнчү, сугу, температура үзгәрү, тавыш, химик матдә һ.б.ш.) тәэсиренә җавап кайтару үзлеге. *Тере организмнарда тынычсызланучанлык матдәләр алмашын яхшырту һәм тирәлекнең зарарлы шартларыннан саклануны тәэмин итә торган файдалы җайланма сыйфатында барлыкка килгән.* Гомуми биология

**ТЫНЫЧСЫЗЛА́У** *ф.* 1) Физик яктан уңайсызлык китерү, авырттыру, борчу. *Уң кулының урта бармагына эт тырнагы чыккан икән, шул җанга тиеп, тынычсызлап бара иде, тырыша торгач, эт тырнагын, канатып, тамыры белән йолкып чыгарды.* А.Гыйләҗев. *Әлеге егәр китә башлау гына тынычсызлый, төнлә йоклатмый, яралар сызлый.* Г.Якупова

2) *биол.* Берәр төрле ярсыткыч белән тере организмга яки аның аерым

әгъзасына тәэсир итү. *Сапониннар составындагы әче матдәләр, бөрештергеч үзлекле матдәләр булганлыктан, тәм сизү нервлары очлыкларын тынычсызлап, селәгәй һәм ашкайнату сыекчасы бүленеп чыгуны көчәйтәләр.* Агулы үсемлекләр

3) Туктаусыз борчып, бимазалап тору, тыныч яшәргә ирек бирмәү; комачау итү. *Юл читендәге куакларда сандугачлар шашып сайрый, кыргый гүзәллекне тынычсызламыйм дигән шикелле генә талгын август җиле исә.* Г.Рәхим. *Әнисе әйткән: «Бик алып бирер идем дә, син, көне буе барабан кагып, тынычсызлап, башны авырттырып бетерер идең бугай», – дигән.* Г.Гыйльманов

4) Кемнең дә булса күңелен борчу, күңел тынычлыгын алу. *Билгеле инде, бу хәл мине бик тынычсызлый иде.* Ә.Еники. *Үткәндәге хатирәләр урап-юрап кайта башлый, алар, җаннарны тынычсызлап, адәм балаларын яңадан-яңа сынауларга дучар итәләр.* Г.Гыйльманов

**Тынычсызлап алу** Кыска вакыт эчендә тынычсызлау; аз гына тынычсызлау. *Кыска гына вакыт эчендә күңелне шундыйрак сораулар тынычсызлап алды.* Н.Фәттах

**Тынычсызлап йөрү** Озак вакыт дәвамында тынычсызлау; даими, гел тынычсызлау. *Гел су эчендә тынычсызлап йөргәч... [Аяк] Чалыр да шул, ник чалмасын.* Р.Бәшәр. – *Өйгә килеп тынычсызлап йөрмәгез, – дип, рейдта катнашучыларның үзләрен гаепләде ул.* Байрак

**Тынычсызлап килү** Электән бирле, күптәннән тынычсызлау. *Бер-ике елдан бирле тынычсызлап килә торган сорау инде бу, дөресен генә әйткәндә...* Р.Вәлиева

**Тынычсызлап кую** Бер тапкыр, аз гына тынычсызлау. *Вакыт-вакыт шулай тынычсызлап куйгалый ул безне. Алай гына да түгел, бөтен тынычлыкны ала.* М.Вәлиев

**Тынычсызлап тору** Сөйләү моментында тынычсызлау; һәрвакыт, даими тынычсызлау. *Күңелне рәхәт тынычсызлап торган бу күренешне сүз белән дә кәгазьгә төшерәсе килә, туачак әсәрләрнең ачылмаган хикмәтләрен, әле мәгънәсе абайланмаган тылсымнарын сизәсең.* Ш.Галиев. *Ул тойгы нигәдер борчый аны, рәхәт тынычсызлап тора.* Х.Камалов

**Тынычсызлый башлау** Тынычсызларга тотыну. *Моңарчы әле тулысынча ачыкланып җитмәгән бер уй, яман чир кебек, аны тынычсызлый башлады.* Н.Фәттах

**Тынычсызлый төшү** Тагын да ныграк тынычсызлау; бераз тынычсызлау

**ТЫНЫЧСЫЗЛЫК** *и.* 1) Һәртөрле ыгы-зыгы, шау-шу, хәрәкәт. *Көннәр үткән саен, авылда тынычсызлык арта барганлыктан, Сөләйман көндезләрен түгел, төннәрен дә печәнлектән төшмәде.* К.Тинчурин

2) Тик кенә, тыныч кына тора алмау, әледән-әле хәрәкәтләнеп тору хәле. *[Хәмидә], сауган вакытта күрсәткән тынычсызлыкларын һәммәсен гафу итеп: «Чү, сыеркаем, чү, менә хәзер бетә», – дип юатты.* М.Гафури

3) Тиешенчә тирән йокыга китә алмау, саташу, бүленеп-бүленеп, куркыныч төшләр күреп йоклау халәте. *Уянды да, тынычсызлыгы сәбәбен эзләнеп, борсаланып ятты.* Я.Зәнкиев

4) Курку, шикләнү кебек кичерешләрдән туган борчылу, дулкынлану халәте. *Кызның матур, кара туткыллы йөзенә тынычсызлык чыкты, күзләре берничә минут бөтенләй эчке уйга туктaлган кебек бер җиргә каттылар.* Г.Ибраһимов

5) Бимаза, борчу. *Тик Фарукҗан шатлык хисе кичерә алмады, ниндидер аңлаешсыз бушлык, тынычсызлык биләгән иде аны.* Т.Әйди

6) Иҗтимагый ризасызлык, һәртөрле чуалыш. *Татарстанда тынычсызлык булдыру кирәктер, бәлки, бу көчләргә?* Н.Кәримова. *Соңгы көннәрдә рубльнең долларга һәм еврога карата түбән тәгәрәве һәм шул сурәттә нефть бәясенең төшә баруы халык арасында тынычсызлык уятты.* Ф.Фәтхи

7) *күч.* Түземсезлек, көчле кызыксыну хисе, дулкынлану. *Гамбәриянең йөрәге ашкынып тибә башлады, күңеле билгесез бер сөенеч сизенеп, рәхәт тынычсызлык кичерде.* К.Тимбикова

**ТЫНЫШ** *и.* 1) Сөйләгәндә, җырлаганда, укыганда һ.б.ш. процессларда кыска вакытлы тукталыш; пауза. *Җөмләләрне, аларның баш һәм иярчен булуларын нинди аһәң (тон) һәм нинди тыныш (пауза) белән әйтелүләренә карап аера алабыз.* Г.Алпаров. *Соңра акрын гына, сүз араларында кыска-кыска гына тыныш ясап сөйләргә кереште: – Алты кыз баладан соң мин бер ир бала күрдем.* Ә.Еники

2) Берәр эш башкарганда ясала торган тәнәфес. *Ярый, алар шулай йөри торсын, сезнең белән без бераз тыныш ясап алыйк.* Г.Гобәй. *Әнвәр ату интервалын чамалап торды һәм бер тыныш моментында алга ыргылды: нибары егерме-утыз метр араны үтәргә кирәк иде.* Х.Камалов

3) Язуда паузалар урынына куела торган билгеләр. *Минем өр-яңа китабымнан беренче биттәге берничә тыныш арасын күрсәтте.* Г.Бәширов. *Шулай да күпнокталар яисә янәшә кулланылган тынышлар, аерым торган сорау һәм өндәүгә караганда, мәгънә төсмерләрен, әйтелми калган фикерләрне күбрәк җиткерә.* Р.Харрасова

4) *әд.* Шигырьдә шигырь үлчәме өчен мәҗбүри булган юл эчендәге ритмлы тукталыш; буынара; цезура. *Бу урында бик кыска ритмик тыныш барлыгын искә алып, дүртьюллык итеп укырга кирәк.* Х.Туфан. *Шунлыктан без әсәрнең оригиналын һәм хәзерге телгә тәрҗемәсен, тыныш-цезураларны вертикаль сызыклар белән күрсәтеп, бай һәм катлаулы шигъри классикабыздан бер дәрес итеп тәкъдим кылабыз.* Н.Хисамов

5) Коръәндә аятьләрнең ахырларына, озын аятьләрнең бер тын җиткәнче укый алырлык өлешенең башына һәм ахырына куела торган билге (бизәкле җәя, чәчәк, аерым гарәп хәрефләре). *Бер тынышыннан алып икенче тынышка тикле [укы].* Н.Исәнбәт // Коръәннең шул ике билге арасындагы кисәге; аять. *[Хәлфә] бер-ике зуррак шәкерттән берничә генә тыныш Коръән укытып карады.* Ә.Еники. *Тук мәче күк киерелеп утырган Габделхәлим, тыныш араларында, стена сәгате суккандай доңгырдатып: – Амин! – дип әйтеп куя иде.* Г.Ахунов

◊ **Тыныш кую** Әңгәмәне, бәхәсне, сөйләшүне һ.б.ш. туктату, тәмамлау. *Бу юлга Симай мәсьәләсенә шушында тыныш куймыйкмы?* Ш.Маннур. *– Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы! – дип, үзенең шагыйрьлек тормышына тыныш куелганына 1933 елның 15 апрелендә 20 ел тула.* Х.Миңнегулов

**ТЫНЫ́Ш БИЛГЕСЕ** *и.* Язма текстның эчтәлеген һәм пауза, интонация үзенчәлекләрен дөрес чагылдырырга ярдәм итә торган график билгеләр (нокта, өтер, күп нокта һ.б.ш.). *Флёра ханым мине гафу итсен инде: шул тыныш билгеләрен һаман дөрес кенә куя алганым юк.* Ф.Яруллин. *Бер генә тыныш билгесен дөрес куймасаң да, бәяне бер баллга киметәләр, ди бит...* В.Нуруллин

**ТЫНЫ́ШМАУЧАН** *с.* Кешеләр белән тату яши алмый, тыныша алмый торган. *Ләкин безнең бәлачел, тынышмаучан Атамановага яхшылык эшләргә тырышуыбыз арзанлы авторитет яулап алырга теләвебез булып калмасмы?* Г.Ахунов // Шундый кешегә хас. *Тынышмаучан холыклы*

**ТЫНЫ́ШМАУЧАНЛЫК** *и.* Тынышмаучан булу. *Бу тынышмаучанлыгың белән син яңа эшеңдә дә озак утыра алмассың.* И.Нуруллин

**ТЫНЫШУ** *ф.* 1) Дус, тату булу, килешеп яшәү яки эшләү (күпчелек очракта юклык формасында йөри). *Ата-анасы белән дә бер дә тынышмый; соңгы вакытларда бөтенләй шашкан төсле йөри башлады.* К.Тинчурин. *Күршедә генә яшәп тә тыныша алмаган ата казлар белән ни эшләргә инде?* Н.Гариф

2) Сугыш хәрәкәтләрен туктату, килешү. *Мимечләр [солых] сораганнар икән дә, безнекеләр ризалык бирмәгәннәр, бер мимеч солдатын калдырмыйча кырып бетергәнгә хәтле тынышу юк, дип әйткәннәр.* И.Гази

**Тынышып тору** Вакытлыча гына тынышу. *Тынышып торган чакларында бик матур күренәләр.* Р.Рахман

**ТЫ́Н ЮЛЛАРЫ** *и. күпл. анат.* Сулыш алганда үпкәгә саф һава керү һәм кире чыгу өчен хезмәт итә торган әгъзалар (борын һәм авыз куышлыгы, бугаз, трахея). *Һава агымы аның тын юлларын ачып, очкын чәчрәтеп, үрләтеп җибәрә.* Ш.Галиев. *Аны сулыйсың, сулыйсың, ә тын юлларың киңәйгәннән-киңәя, иркенәйгәннән-иркенәя төсле.* А.Хәсәнов. *Сәгыйрьнең күңеле хушланып, тын юллары ачылып китте.* Т.Галиуллин

**ТЫҢ** I *иярт.* Авыр тимер әйберләр бер-берсенә яки йомшаграк әйбергә бәрелгәндә яки берсе өстенә берсе төшкәндә чыккан саңгырау, тонык тавышны белдерә. *Сәгать чылбырын тарттың... тың... тың... тыңк!* Җ.Юнысов

**ТЫҢ** II *и.* Кешегә сиздермичә тыңлап тору

◊ **Тыңга йөрү (бару, чыгу)** Берәр эшне юрау, нинди дә булса билгесез хәлгә ачыклык кертү яки берәр кешенең язмышын белү өчен, кичен кемнең дә булса тәрәзә артына барып, өйдәгеләрнең ни сөйләгәннәрен тыңлап йөрү (гадәттә беренче ишетелгән сүзгә карап юраганнар)

**ТЫҢГЫЧЛА́У** *ф. диал. к.* **дыңгычлау**. *Яфраклар, чәчәкләр – ак кына, Җыям да, салам да мендәргә тыңгычлап, Баш куеп шуларга, талам мин йокыга.* Ә.Баян. *Минеке дә берни сизми, әллә ниткән куе ис кенә тулган кебек. Тыңкычлап тутырганнар диярсең [борынны].* Г.Каюмов

**ТЫ́Ң ИТҮ** *ф.* Калын, авыр тимер нәрсә бәрелеп саңгырау тавыш чыгу. *Тың иттереп берне сукты Сабирҗан агай, шунда ук Борһан гөпелдәтеп дәү чүкечен китереп төшерде.* М.Шәрифуллин

**ТЫҢКАУ** *с. диал. к.* **тыңкыш**. *Тыңкау малай*

**ТЫҢКЫШ** *с.* **1.** 1) Һаваны иркен үткәрми торган, тыгылган (борын тур.). *Чәйнектә мәтрүшкә пеште, аның хуш исе минем тыңкыш борынга да килеп керде.* Ш.Маннур. *– Галошыңны салып как әле, – диде ул, гомер ачылмас тыңкыш борынын тартып.* Н.Хәсәнов

2) Борын тыгылганга күрә, тонык, саңгырау чыга торган (тавыш тур.). *– Фәизов, син нәрсә саботаж ясыйсың? – дип тотынды ул тыңкыш тавышы белән.* Х.Камалов. *Хәбәр әйтелеп беткәч, гимнның үзен дә рәттән ике мәртәбә уйнаттылар да тыңкыш тавышлы халык артистын җырлатырга керештеләр.* Ф.Баттал

3) Борыны тыгылган, борын эче белән сөйли торган (кеше тур.). *Җәүдәт үсмер чорына кереп килгән елларда күршеләре Галирахман абзыйның сакау, җитмәсә, тыңкыш малае бар иде.* А.Хәлим. *Канифә баштарак: «Әллә кемнәрне сыйлап ятырга», – дип чабаланып караган иде дә, Мәхмүт усал гына итеп (тыңкыш кешене усал була диләр, хак икән): «Синең эшләп алган хәерче акчаңа шулай яшибез дип беләсеңме әллә?» – дигәч, буйсынмый хәле булмады.* Н.Көбәш

**2.** *рәв. мәгъ.* Саңгырау тавыш чыгарып. *Хәтта борын белән тыңкыш сөйләүчеләрне дә чыгаралар.* Татарстан яшьләре. *Тавышы тыңкыш чыга, борыны тыгыла.* Сөембикә

**3.** *и. мәгъ. хурл.* Борын аша сөйли торган кеше. *– Әй сез, мужиклар, ягъни мәсәлән, тыңкышлар, мәдрәсә тәртибен бозарга сезгә кем кушты? – диде.* К.Тинчурин. *Нәрсә сөйлисең, тыңкыш, авызың сөйләгәнне колагың ишетәме?* Шәһри Казан

◊ **Тыңкыш танау** Саңгырау тавыш белән сөйләшкән кешеләргә карата яратмыйча әйтелә. *Әйдәгез, берләшеп, шул тыңкыш танауларга үч итеп, Батырхан әфәндене сайлыйк.* К.Тинчурин

**ТЫҢКЫШЛАНУ** *ф.* Тыңкышка әйләнү, борын тыгылу, тыңкыш тавыш чыгара башлау. *Телләрнең йозагы төшә, моңарчы бер айга ун сүз дә әйтә алмаган, тыңкышланып, сакауланып мыгырдаган мыштыбыйлар да Цицеронга әйләнә!* А.Гыйләҗев. *Анасы, елавыннан туктап, тыңкышланган борынын тарта-тарта, Ярмөхәммәт янына килде дә кочаклап алды.* Р.Батулла

**ТЫҢКЫШЛЫК** *и.* Тыңкыш булу. *Бер туганыбыз грипптан сукырая язды, икенче туганыбызның борынында тыңкышлык әле дә бетми.* Ф.Яруллин. *Тавышы да шул ук. Чак кына тыңкышлыгы сизелә.* А.Хәсәнов

**ТЫҢЛАГЫЧ** *и.* Радио, телефон, компьютер һ.б.ш. аппаратларда тыңлау өчен колакка киелә яки куела торган махсус җайланма; колакса, наушник.

*Яшьләре бу шомлы уйлардан колакларына радио тыңлагычлары киеп, карашларын кара күзлекләр белән томалап качалар.* Н.Гариф

**ТЫҢЛАМАС** *с.* **1.** 1) Кеше сүзен тыңламый, әйткәнне эшләми, үтәми торган (кеше тур.). *Мин бит аның мондый ук тыңламас кеше икәнлеген белми идем.* Р.Вәлиева. *Җыен тыңламас малайлар гына икән бу сыйныфта.* Сабантуй

2) *күч.* Ниндидер сәбәпләр аркасында көйсез, җайсыз булган; тиешенчә тормаган, йөрмәгән һ.б. (җансыз нәрсәләр тур.). *Ул: «Синең яныңда бер бөтерелү үзе зур бәхеттер», – дигәндәй, мөлдерәп Гөләндәмгә карый һәм, кызның үз турысына җиткәч, горур башын янә бер түбән иеп, ымсындырып дәшүенә түзә алмый, тыңламас аякларын сөйрәп тыпырдый башлый.* Ф.Яруллин. *Алтын сыман тыңламас чәчләрен артка бәйләп куйган.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* Әйткәнне тыңламый торган кеше. *Тыңламас үтерсәң дә аңламас.* Әйтем. – *Тыңламаслар белән ничек эш итәргә кирәклеген беләбез лә, – диде ул елмаеп.* Ш.Маннур

**ТЫҢЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тыңлау** (*1–4 мәгъ.*). *Сәгать өчтә доклад әйбәт тыңлана, чөнки инде көн бетүгә авышкан, ике сәгатьтән эш көне тәмам, аннан җылы, ышык өеңдә телевизордан хоккей, футбол карыйсың.* М.Мәһдиев. *Тик шунысы бар: ул сүзләр, тыңлаганда, бик тә кызык, файдалы, эшлекле сүзләр төсле тыңлана, чөнки теге иптәшләр, дистә еллар буена анда утырып, телләрен тәмам чарлап бетергәннәр иде инде.* М.Вәлиев

2) Яхшырак, ачыграк ишетер өчен, бик зур игътибар белән тыңлау. *Сәетҗан абыйның ачуы басылды, Илдар ишеккә караштырып көйсезләнде: икесе тик аны көттеләр, баскыч ягыннан лифт тавышы ишетелгән саен, сагаеп тыңландылар.* М.Маликова. *Тыңланып ята-ята, йокыга киткәнемне сизми дә калганмын.* Р.Габделхакова

**Тыңлана башлау** Тыңланырга тотыну. *Кинәт ул еракта нәзек тавыш белән машина гөжләгәнен ишетеп алды, курчак солдаттай сикереп торды, чәч арасына кереп тулган яфрак кисәкләрен җиргә койды һәм колагын тавыш килгән якка куеп тыңлана башлады: ул көткән машина кил(ә)ме?* А.Гыйләҗев. *Үзе җиргә сузылып ятып тыңлана башлады.* Х.Камалов

**Тыңланып йөрү** Озак вакыт дәвамында тыңлану, даими тыңлану. *Шул тирәдә тыңланып йөргән карчыгы килгән дә учы белән шалт тегенең пеләшенә!* М.Маликова

**Тыңланып тору** Сөйләү моментында тыңлану. *Ул, абына-сөртенә, өйгә керде, бусаганы атлап узгач, тын тартырга куркып тыңланып торды.* А.Гыйләҗев. *Аптырагач, Денис яңадан өйгә кереп, бераз тыңланып торса, маэмай шыңшуына охшаш аваз ишетелгәндәй тоела.* Ә.Баянов

**ТЫҢЛАТТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тыңлату**. *Җырлаттыра, Һәммәсен дә Тыңлаттыра.* Ш.Галиев. *Чөнки әни җырлаганда, минем дә аны кешегә тыңлаттырасым килми иде.* Р.Вәлиев

**ТЫҢЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тыңлау**. *Шулай да, бөтен бер авылга бердәнбер кыз икәнлегегезне искә алып, без сезгә Высоцкийны да, бүтәнен дә тыңлатырбыз.* М.Мәһдиев. *Шушы кичәгә ярардае юкмы дип, Мәтин бәй миңа күп кенә кассеталар тыңлатты.* С.Ибраһимова

2) Берәр эш эшләргә күндерү, үз сүзен үткәрү; буйсындыру. *Сез, әле директор булып та, үз хезмәткәрегезне тыңлата алмагансыз.* Т.Гыйззәт. *Ул кешеләрне Алла сүзе белән тыңлатып, бер-берсенә изгелек, яхшылык эшләткән, тәмле сүзләр әйтеп яшәргә өйрәткән, ди.* З.Зәйнуллин

3) *иск.* Өйрәнгән, бирелгән сабакны сөйләтү. *Хәзрәт тагын сабакны тыңлатырга кереште.* М.Гафури. – *Якуб, Шакир, чыгып басыгыз, – дип, әкрен генә боерык бирә [хәлфә] сабагын тыңлата алмаган шәкертләргә.* Ә.Фәйзи

**ТЫҢЛА́У** *ф.* 1) Кешеләр, җанлы-җансыз нәрсәләр чыгарган тавышны, авазларны ишетү, колак белән кабул итү. *Яшьлегендә опера җырчысы булган, ә хәзер композиция өстендә уңышлы эшләп, берсеннән-берсе матур көйләр язган Сара Садыйкова хорын яратып тыңлый идем.* Л.Ихсанова. *Эштән буш вакытларда аның каютасында радиодан концертлар тыңлый идек.* С.Сабиров

2) Башкаларның үзара нәрсә турында сөйләшүен яшерен рәвештә белергә тырышу, сиздермичә колак салу, башкаларның сөйләгәне белән кызыксыну. *Аның ашыгыч эше юк иде, ул Мансурны саклады, әллә ничә тапкыр аның ишеге төбенә барып тыңлап торды.* Г.Әпсәләмов. *Өстәп шуны гына язып куям: безнең авылда сугыш вакытында Нәгыймә апа белән Марзия апаның сөйләшүен әни тыңлап торган.* Т.Миңнуллин

3) Кемнең дә булса эчке әгъзаларының (йөрәкнең, үпкәнең) эшчәнлеген махсус аппарат ярдәмендә яки колакны куеп тикшерү. *Колагын күкрәгенә куеп тыңлый.* Т.Гыйззәт. *Фельдшер сабыр гына кыяфәттә малайның пульсын санады, йөрәген тыңлады.* М.Мәһдиев

4) Җинаять яки гражданлык эшен судта тикшерү. *Урлау турындагы эшне тыңлау тагын кичектерелде.* М.Вәлиев. *Танылган группировкалар турындагы эшне тыңларга журналистлар да кертелде.* Ватаным Татарстан

5) Фән нигезләренә төшенү, берәр нәрсәгә өйрәнү өчен лекцияләргә йөрү. *Яшь чагында Платон күренекле галимнәрдән сабак тыңлый.* А.Тимергалин. *Минем җаным түзмәде: «Мин Сезнең лекцияне моннан ары тыңлый алмыйм», – дидем.* М.Галиев

6) Кемнең дә булса әмеренә, боерыгына буйсыну, таләпләрен, әйткәнен үтәү, карышмау. *Берәрсе каршылык күрсәтсә, тыңламаса, ул нишләгәнен белештерми, әлеге көч каршысындагы киртәне җимерми торып тынмый.* Ф.Садриев. *Ни генә булса да, Динә тыңлый белә.* М.Әмирова

7) Кемгә дә булса буйсынып, тиешенчә эшләү, хәрәкәтләнү (идарә итә торган машиналар, әйберләр, тән әгъзалары тур.). *Артыннан йөгермәкче булам, аяклар тыңламый.* З.Хәким. *Эш эшләргә тотынса, куллары тыңламый, иптәшләреннән калмаска тырышып, укуга тотынса, сызлауга түзә алмый-*

*ча, башын тота да караватка каплана.* Ф.Әмәк

8) Кемнең дә булса киңәше, үтенүе буенча эш итү. *Гәрчә бик алай атлыгып тормаса да, авылдашының сүзен тыңлый, барырга була.* К.Миңлебаев. *Ләкин кранчы кызның йөзендә үзгәреш күренмәде, ул бары тик җирдәгеләрнең әмерен генә тыңлый, аны күрми дә, ишетми дә иде кебек.* Р.Вәлиев

9) Кемнең дә булса сүзләрен игътибарга алу. *Картлар сүзен тыңлаучы юк хәзер*

10) **тыңла(гыз)**. Кемнең дә булса игътибарын үзенә җәлеп итү өчен өндәү сүз итеп кулланыла. *Тыңлагыз, менә нилэр язылган: теплоход Владимировка пристаненда торган вакытта эчеп һәм сугышып йөргән өчен һәм шуның белән бөтен команда өстенә тап төшергән өчен, практикант Әсәдуллин Харисны теплоходтан төшереп калдырырга приказ бирәм.* С.Сабиров. *Тыңлагыз, тыңлагыз, ишетми калдык, димәгез!* Ф.Баттал

11) **тыңлыйм**. Кемнең дә булса боерыгын үтәргә риза булуны яисә әйткән сүзләрен тыңларга әзер булуны белдерә. *Тыңлыйм, Шәрифҗан әфәнде, соңыннан!* И.Юзеев. *Тыңлыйм, иптәш командир!*

12) *күч.* Теге яки бу кешенең үтенечен канәгатьләндерү, сораганын бирү, әйткәнен эшләү. *Акча сорап барсам, тыңламасмы икән?*

**Тыңлап алу** Тиз арада гына тыңлау. *Ашау алдыннан җыру тыңлап алыгыз, әфәнделәр!* И.Юзеев. *Ара-тирә, арыгач, радио тыңлап алам.* М.Мәһдиев

**Тыңлап бетерү** Барысын да тыңлау, беткәнче тыңлау. *Тыңлап бетергәч әйтте: – Ялгышасыз, иптәш Таҗиева, Габделбарыев үзе өчен бер энә дә сорый торган кеше түгел.* М.Мәһдиев. *Көн эчендә ниләр эшләнгәнен барлап, йомыш белән килгәннәрне тыңлап бетергәч, алар Вәлишин белән тагын икәүдән-икәү калдылар.* М.Маликова

**Тыңлап тору** Сөйләү моментында тыңлау; күпмедер вакыт тыңлау. *Егет дәшми-нитми сүзсез тыңлап торды да: – Ярый, карап карармын әле, – дип, икеле җавап кайтарды.* Г.Ибраһимов. *Ләкин мин аның үгет-нәсыйхәтләрен тыңлап торыр хәлдә түгел, башымда мең төрле уйлар кайный иде.* В.Нуриев

**Тыңлый башлау** Тыңларга тотыну. *Атна-ун көн үтүгә, Заһри саргаеп кипте, күрше-күлән белән сөйләшкәндә, колагына кулын куеп тыңлый башлады.* М.Мәһдиев. *Әңгәмәдәшен игътибар белән тыңлый башлаган Вахит хәзер инде Нурулланың тизрәк төп сүзгә тотынуын көтә иде.* М.Вәлиев

**Тыңлый бирү** Тыңлавын дәвам итү; бернигә дә карамый тыңлау. *Егет болай сөйли: – Ике якның үгет-киңәшләрен, бер-берсенә карата фикерләрен тыныч кына тыңлый бирдем.* Р.Низамиев. *Моңа каршы нәрсә дип әйтәсең дигәндәй, Җилдем баш селкеп, баш иеп кенә тыңлый бирде.* Р.Рахман

**Тыңлый тору** Озак вакыт дәвамында тыңлау; һәрвакыт тыңлау. *Урманда син танымаган төрле-төрле кошлар чүкердәшә, тыңлый торгач, җырларына тәмам ияләшеп, ишетми үк башлыйсың.* Ш.Галиев. *Беләм птамышты: хатын да, түшише дә безнең һәр сүзне тыңлый торалар.* Ф.Баттал

**ТЫҢЛАУЛЫ** *с.* Тыңлый торган, тыңлаучан. *Өй эчендә ифрат тыңлаулы, хәленнән килгәнчә әнисенә булышып, ярдәмләшеп йөрүче бала, ишегалдына чыккач, нигә үзгәрә?..* А.Гыйләҗев. *Ә бит колхозның иң тыңлаулы, иң юаш үгезе иде үзе.* В.Нуруллин

**ТЫҢЛАУСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тыңлатып булмый торган. *Тыңлаусыз бармаклар сымак аерым-аерым йөрсәк, ул солдатлар безне өч көн эчендә тетеп кенә ата.* В.Имамов

2) Үзсүзле, сүз тыңламый, әйткәнне үтәми торган. *– Аһ, ахмак малай, адәм улы! – дип ачуланырга да керешкән аны Шүрәле. – Нинди тыңлаусыз бәндә син?* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Тыңлаусызны да тыңлата белүче.* Әйтем. *Ә тыңлаусызлары, --- көндәлек чүпләрен матур сумкаларга салып, үзе белән ала.* Ватаным Татарстан

**ТЫҢЛАУСЫЗЛАНУ** *ф.* Сүз тыңламый башлау, тыңлаусызга әйләнү

**Тыңлаусызлана бару** Көннән-көн ныграк тыңлаусызлану

**Тыңлаусызлана төшү** Бераз тыңлаусызлану; тагын да тыңлаусызлану

**Тыңлаусызланып йөрү** Еш кына тыңлаусызлану

**Тыңлаусызланып китү** Кинәттән тыңлаусызга әйләнү

**Тыңлаусызланып тору** Әле, хәзерге вакытта тыңлаусызлану

**ТЫҢЛАУСЫЗЛЫК** *и.* Тыңлаусыз булу. *Шул чакта ике бала туганын, әниемне шәһәргә мәңге алып барып булмаячагын да аңлаткач, Туфан абый артык басым ясамады, тыңлаусызлыгым өчен үпкәләвен дә сиздермәде.* Сәхнә. *Малайның тыңлаусызлыгы картны тәмам аптырашка калдырды.* Мәдәни җомга

**ТЫҢЛАУЧАН** *с.* Кеше әйткәнгә күнүчән, күндәм, карусыз. *– Дөрес күңелле, тыңлаучан адәм, – дип, Гыймадины Габдулла ишан үзенә кул асты йомышына алды.* Г.Ибраһимов. *Сирәкләнгән чәчен сыйпаштырып, гүя ул карусыз тыңлаучан малай чагына әйләнеп кайтты.* К.Миңлебаев

**ТЫҢЛАУЧАНЛЫК** *и.* Тыңлаучан булу сыйфаты. *Беренче чиратта яшь хезмәткәрнең тыңлаучанлыгы күзгә бәрелде.* Идел

**ТЫҢЛАУЧЫ** *и.* 1) Кемнең дә булса сөйләвен, чыгышын тыңлап торучы; тамашачы. *Кызны юатырдай сүзләр таба алмадым. Хәер, аңа юатучы түгел, тыңлаучы кирәк иде.* Ф.Яруллин. *Хөсни картка тыңлаучы гына булсын.* Г.Гыйльманов

2) Югары уку йортларына лекцияләр тыңларга йөрүче, вакытлы курсларда укучы. *[Вәһапов] Ирекле тыңлаучы сыйфатында табигать факультетында лекцияләргә йөри.* И.Рәми. *1908 елдан Россия университетларында ике меңгә якын хатын-кыз ирекле тыңлаучы булып белем ала башлый.* Т.Биктимирова

**ТЫҢЛАШУ** *ф. диал.* 1) Яхшырак ишетер өчен зур игътибар белән тыңлау

2) Кем дә булса әйткәнне үтәү, карышмау. *Тыңлашмаса сабый бала – җикермә.* Р.Ханнанов

**Тыңлашып тору** Әле, хәзерге вакытта тыңлашу. *Габбас аскы өйдән*

*килгән тавышларга колак салгалап, тыңлашып торды.* Г.Ахунов

**ТЫҢ-ТУК** *иярт.* Каты әйберләр бер-беренә бәрелгәндә яки берсе икенчесенә сукканда бер зыңылдап, бер тукылдап чыккан тавышны белдерә

**ТЫ́Ң-ТУЛЫ** *с. сир.* Туп-тулы. *Су белән тың-тулы чиләк*

**ТЫҢЧАН** *с. диал. к.* **тыңлаучан**. *Мин чичәм, Мин алардан, буйсынып, тыңчан бәрән төсле китәм.* С.Сүнчәләй

**ТЫҢЧЫ** *и.* 1) Кемне дә булса күзәтүче, кешеләр сөйләшкәнне кемгә дә булса сөйләп, җиткереп торучы кеше. *Мин эшнең ни белән бетәрен белер өчен тыңчы булып түбән өйгә төштем.* Ш.Маннур. *Хан киткәнгә әллә ни вакыт та үтми, күрәсең, чүл арты ялмавызының тыңчылары ничектер ялмавызга шәһәр гаскәрсез калды, сугышырга туры килсә, каланы яклаучы юк, ә дәүләтнең казнасы хан сарае астында ятканын хәбәрлиләр.* В.Ильская

2) *диал.* Тыңлаучан, күндәм

**ТЫП** I *иярт.* Биегәндә, сикергәндә, каты итеп басканда яки эре тамчы тамганда чыга торган тавышны белдерә. *Яңгыр шыбырдаганы җанга тия, эре тамчылар калай тәрәзә төбенә шулкадәр каты килеп төшә ки, ул гел башка сугып торган кебек шакылдый: тып та тып, тып та тып.* И.Нәбиуллина

**ТЫП** II *рәв.* Берәр эш-хәрәкәтнең кинәт һәм тулысынча тукталуын белдерә; шып. *Атын куалап, мулла йортына таба чапты һәм, анда җитүгә, тып туктады: йорттан морҗасы тырпаеп торган коры мич кенә утырып калган иде.* И.Хуҗин

**ТЫП-** *кис.* Кайбер сыйфатлар һәм рәвешләр алдында килеп, шуларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Өй эче тып-тын.* Г.Әпсәләмов. --- *Торна көтүләре тып-тыгыз.* К.Булатова. *Әйе-әйе, тып-тымызык тынлык.* Г.Гыйльманов

**ТЫ́П ИТҮ** *ф.* 1) Зур булмаган каты әйбер төшеп, бәрелеп, саңгырау тавыш чыгару. *Симез тәкә, хуҗасының сарайга кергәнен күргәч, «беләм мин синең ниятеңне» дигән кебек, тып итеп аяк тибеп куйды.* Г.Сабитов. *Менә тып итеп имәннән бер чикләвек төшә, бераздан тагын берәү.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Көтмәгәндә, кинәттән берәр эш-хәрәкәт башкарылу. *Тып итеп вагон артыннан каршысына килеп чыккан шәүләне күргәч, Наилә коелып иңде, батон белән сөт шешәсе салган чүпрәк букчасы кулыннан төшеп китте.* А.Гыйләҗев. *Шул вакыт тып итеп мин килеп җитәм Кызылъярга.* Г.Якупова

**ТЫ́П-ТЫП** *иярт.* **1.** Эре тамчылар бер-бер артлы тамганда, каты җирлеккә нәрсә дә булса бер-бер артлы төшкәндә, каты өслеккә нык басканда, сикергәләгәндә чыккан тавышны белдерә. *Әй берзаман муенын кәкрәйтеп, койрык чәнчеп, төп-төз аяклары белән тып-тып басып юыртып китә, агай!* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тамчылар төшкәләп, еш-еш нindидер вак нәрсәләр коелып, тонык тавыш чыгару. *Җир шарыннан атлый бала: Ул кагынып Алулары, Тыптып басып Барулары!* Г.Әпсәләмов

**ТЫП-ТЫ́П ИТҮ** *ф.* Тып-тып иткән тавышлар чыгару. *Тәпи йөри башлый яңа гына, тып-тып итеп, тып-тып итеп.* Г.Афзал. *Үлде, ахрысы, дип, Һаҗәр аның янына барса, анда тыптып итеп су тибеп чыкканын күреп хәйранга кала.* Сөембикә

**ТЫП-ТЫ́П КИЛҮ** *ф. к.* **тып-тып итү**. *Әнә имчәк кебек сузылып төшкән таш очларыннан мәгарә идәненә, тып-тып килеп, күз яшьләре тама.* В.Имамов

**ТЫПЫЛДАТУ** *ф.* 1) *к.* **тыпырдату**. *Шиблет кигәннәр табаннарын тыпылдатып, үкчәле читек кигән шәкертләр чәпелдәтеп, берсе икенчесен алмаштырып биергә керештеләр.* С.Кудаш

2) Бару, кайту, гомумән җәяү берәр якка юнәлү. *Вакыт иркен: халыкның эштән кайткан чагы, балаларның да арып-талып бакчадан өйгә таба тыпылдатулары иде.* Ф.Җамалетдинова

**Тыпылдата башлау** Тыпылдатырга керешү. *Кыз, әтисен күрүгә, аякларын тыпылдата башлады.* Р.Вәлиева

**Тыпылдатып алу** Бераз тыпылдату. *Бармакларын тыпылдатып алды*

**Тыпылдатып кую** Бер тапкыр тыпылдату. *Ул, музыка ишеткән саен, аягы белән тыпылдатып куя, сикергәли.* М.Вәлиев

**Тыпылдатып тору** Сөйләү моментында тыпылдату. *Аягын тыпылдатып тору*

**ТЫПЫЛДА́У** *ф.* Тып-тып итү, тып-тып килү. *Аз гына тоныкланып торды да янә тыпылдарга тотынды.* М.Әмирханов. *Тәрәзә төбендәге калайга бәрелеп, яңгыр тамчылары тыпылдады.* М.Кәбиров

**Тыпылдап кую** Бер тапкыр тыпылдау. *Тәрәзә төбендә тамчылар тыпылдап куйды*

**Тыпылдап тору** Озак вакыт дәвамында тыпылдау; сөйләү моментында тыпылдау

**Тыпылдый башлау** Тыпылдарга тотыну

**ТЫПЫЛДАШУ** *ф.* Күп, еш булып тып-тып итү, тып-тып килү. *Барысының да бүген тавышы бар: Тыпылдашып тама тамчылар.* Ә.Юныс

**Тыпылдаша башлау** Тыпылдашырга тотыну

**ТЫПЫЛДЫК** *с. диал.* **1.** Тып-тып итеп тора торган, тыпылдап торган. *Тыпылдык туп*

**2.** *и. мәгъ.* Тып-тып иткән тавышлар чыгара торган әйбер. *Шап-шоп шапылдык, Басма өстендә тыпылдык.* Табышмак

**ТЫПЫ́Н-ТЫПЫН** *рәв. диал.* Әкрен генә, сак кына. *Тыпын-тыпын йөрү*

**ТЫПЫРДАВЫК** *с. сөйл.* **1.** 1) Тыпырдап тора торган, тыпырдап биеп торган. *Тыпырдавык бала*

2) *күч. кимс.* Юк эш белән йөри торган. *Тыпырдавык егет*

**2.** *и. мәгъ.* Тыпырданып торучы кеше, тыпырдап биеп торучы. *Мин аларга кем? Коры бер тыпырдавык. Идән таптаучы.* Ф.Хөсни

**ТЫПЫРДАНУ** *ф.* Бер урында ешеш баскалап тору. *Яр буендагы окобыннан моны күзәтеп торган командир ике куллап башына тотына һәм яраланган кеше кебек ухылдый, тыпырдана, тар траншеяда бәргәләнә-суккалана.* Х.Камалов. *Урыннарында аларга куәт биреп, тыпырданып, дуслары тора.* Д.Каюмова

**Тыпырдана башлау** Тыпырданырга тотыну. *Аягына салкын үткән ахры, егетем баскан урынында тыпырдана башлады.* Р.Вәлиева

**Тыпырданып алу** Бер яки берничә тапкыр тыпырдану. *Мәче төшә, дип шатланып, баскан җирендә тыпырданып алды кыз.* Н.Каштанов. *Үзе дә каты карга чыгып баскач, биегән сыман итеп, куанычыннан олтанлы зур итекләре белән шап-шоп тыпырданып алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Тыпырданып тору** Сөйләү моментында тыпырдану; озак тыпырдану. *– Бар, янымда тыпырданып торма әле, – дип, ачуланып куып җибәрде ул аны.* Р.Вәлиева

**ТЫПЫРДАП** *рәв.* Тыпыр-тыпыр итеп, вак тибешле адымнар белән. *Кызның тыпырдап биюе кырык бишенче елның тугызынчы маен искә төшерде.* М.Мәһдиев. *Алар, барган уңайга гармун уйнатып җырлый-җырлый, яшел чирәмдә тыпырдап биеп тә киталәр.* А.Вергазов

**ТЫПЫРДАТУ** *ф.* 1) Аякларны, бармакларны ниндидер каты өслеккә ешеш бәреп, тыпыр-тыпыр иткән тавыш чыгару. *Аннары, кулларын селки-селки, аякларын ешрак тыпырдата, куллары белән тотып, башын әйләндерә, билләрен...* Т.Әйди. *Әхмәтҗан үзе тунын кигән дә түр башында утыра, бүрәнә күк бармаклары белән өстәл өстен тыпырдата: әнә, тапсагыз алыгыз, янәсе.* Л.Гыймадиева

2) *сөйл.* Тыпыр-тыпыр иткән тавышлар чыгарып бию. *Биергә бик ярата. Куанычына түзә алмый, Күр, ничек тыпырдата.* Р.Вәлиева. *Ничек чая тыпырдата ул! Биюне коеп кына куя бу зифа гәүдә!* Р.Камал

**ТЫПЫРДАТЫП** *рәв.* Тыпыр-тыпыр иткән тавышлар чыгарып (бию, атлау һ.б.ш. тур.). *Үзебез программа төзибез, үзебез чатнатып шигырь сөйлибез, тыпырдатып биибез, сагышлы мәхәббәт җырларын сузабыз.* Л.Шагыйрьҗан. *Ата-бабаларың намазга дип утырган идәннәрне тыпырдатып биергә ничек җөрьәт итмәк кирәк?* Г.Әдһәм

**Тыпырдата башлау** Тыпырдатырга тотыну. *Ашап хушланган бала, велосипед педале әйләндергәндәй, җәһәтҗәһәт, алмаш-тилмәш тәпиләрен тыпырдата башлады.* Г.Сабитов. --- *егет, үзе дә сизмәстән, бармакларын тыпырдата башлады.* Р.Вәлиева

**Тыпырдатып алу** Берникадәр вакыт, аз гына тыпырдату. *Тәкъдим ителгән урынга утыргач, лаклы туфлясын, нервланып, тыпырдатып алды.* Ә.Сафиуллин. --- *Әлфия, пырдымсызланып, аякларын тыпырдатып алды.* Т.Галиуллин

**Тыпырдатып кую** Кинәт кенә, бер тапкыр тыпырдату. *Саша бик нык итеп бер урында аягын тыпырдатып куя.* А.Әхмәт. *Полковник кресло култыксаларында яткан бармакларын тыпырдатып куйды.* А.Расих

**Тыпырдатып тору** Озак вакыт дәвамында тыпырдату; сөйләү моментында тыпырдату. *Аякларын тыпырдатып торган малай янына килеп нәрсәдер эндәште булса кирәк.* И.Нуруллин

**ТЫПЫРДА́У** *ф.* 1) Каты нәрсәгә, җиргә бер-бер артлы төшеп, басып, сикергәләп, тыпыр-тыпыр иткән тавыш чыгару. *Каршы землянка янында атларның тыпырдавы, пошкыруы, тезген чылбырларының зыңлавы һәм кемнәрнеңдер аерата ачык, ләкин ят тавыш белән сөйләшүе ишетелде.* А.Расих. *Колакка нинди ятышлы-ягымлы аның нәни тояклары белән тыпырдавы!* М.Хуҗин

2) Бию хәрәкәтләре ясап, аяклар белән еш-еш басу. *Бармаклары – кылларны чиртүдән, аяклары тыпырдаудан бүтәнне белми.* М.Маликова. *Әле «Әпипә»гә, әле «Калинка», «Лезгинка», «Краковяк»ка тыпырдады кыз.* Г.Әдһәм

3) Берәр эш эшләргә дәртләнеп, бер урында аякларны биетеп кую, тик кенә басып тора алмау, бер урында сикергәләнү, еш-еш таптану. *Мәрьямбикә эссе табага басты: тыпырдый, очына, оныкларының әле берсенең, әле икенчесенең аркасын барып кага, ни кылырга белми, башы тәмам миңгерәүләнде.* А.Гыйләҗев. *Аяклар үзеннән-үзе тыпырдый.* М.Маликова

4) Арлы-бирле сугылу. *Тыпырдый, боргалана, ычкынып качмак була.* Г.Сабитов

5) Тып-тып иткән тавышлар чыгарып, еш-еш таму. *Әй, тамчылар икән бит, өй түбәсендә тыпырдап бииләр икән!* М.Хуҗин. *Куе тирәкләрдә кошлар чыркылдашты, ара-тирә, алар пырхылдап очып киткәндә, яфраклардан чык тамчылары тыпырдап өстемә коелды.* Д.Бүләков

6) *күч.* Еш тибү; кагу (йөрәк тур.). *Шулай итеп, йөрәк тыпырдаудан туктады, бүрек эче иркенәеп калды.* Ф.Хөсни

**Тыпырдап алу** Аз гына тыпырдау. *Әхмәт вальс көенә бер тыпырдап ала да Мәрьям каршына килеп баса.* Ф.Яруллин. *– Мин әзер, җибәр яучыңны, – дип, егет каршында бер тыпырдап ала да иптәш кызлары белән юлын дәвам итә.* Г.Габидуллина

**Тыпырдап кую** Бер яки берничә тапкыр гына тыпырдау. *Карчык кинәт утка пешкән кебек баскан урынында тыпырдап куйды, куллары хәрәкәткә килде.* Х.Камалов. *Шактый ук күшеккән бай баскан урынында тыпырдап куйды.* И.Сираҗи

**Тыпырдап тору** Озак вакыт тыпырдау; сөйләү моментында тыпырдау. *Нурания баскан урынында тыпырдап торды: ни алырга, ни куярга белмәде.* Р.Камал

**Тыпырдый башлау** Тыпырдарга керешү. *Шунда ук кабина түбәсендә эре-эре яңгыр тамчылары тыпырдый башлады.* Г.Сабитов

**ТЫПЫРДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **тыпырдау**. *Матур сөйләшеп торган кешеләр төрткәләшкән терсәкләр, тыпырдашкан аяклар, күтәрелгән күлмәкләр, тузгыган чәчләр йомгагына әверелә.* Ш.Галиев

**Тыпырдаша башлау** Тыпырдашырга тотыну. *Музыка тавышын ишетүгә, кызлар тыпырдаша ук башладылар.* Р.Вәлиева

**Тыпырдашып алу** Бер тапкыр яки кыска вакыт аралыгында тыпырдашу. *Барысы да бөтен: ишегалдында җанга газиз печән кибәне исе, абзарда сыер мышный, сарыклар тыпырдашып ала, мунча артында пуф-пуф итеп Капитан йоклый, өйалдыннан тәмле шулпа исе килә, күктә йолдызлар*

*калка, чикерткәләр чурлый, чык төшә.* М.Мәһдиев

**Тыпырдашып кую** Кинәт тыпырдашу. *Ара-тирә сыер мышнап ала, сарыклар тыпырдашып куялар.* М.Мәһдиев

**Тыпырдашып тору** Сөйләү моментында тыпырдашу; озак вакыт дәвамында тыпырдашу. *Базарда җәй булса – кара-чутыр чегән хатыннары төсле каешланып, кышкы суыкларда, туңмас өчен дип, ярты стаканны җибәреп, мех бияләй кигән кулларын суккалый-суккалый, көннәр буе тыпырдашып торалар бит, бичаралар.* Г.Галиева

**ТЫПЫРДЫК** *с.* 1) Бер урында тик тора алмыйча, гел тыпыр-тыпыр килеп тора торган. *Әй бәтием, бәтием, Бәләкәчем, тәтием. Тиктормас аяккаем, Тыпырдык тояккаем.* Р.Вәлиева

2) Түземсез, көтәргә яратмый торган, көтәргә түземлеге булмаган. – *Тыпырдык кеше инде ул шундый, исең китмәсен, – диде әнисе аны юатып.* Кызыл таң

**ТЫПЫ́Р-ТЫПЫР** *иярт.* **1.** Каты басып биегән вакытта яки җиргә каты итеп еш-еш басканда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Концертта, Тыпыр-тыпыр, Тыпыр-тыпыр, Сылу кызкай өзә генә!* Р.Миңнуллин. *Зәй юлыннан җиде-сигез малай, тыпыр-тыпыр, ялан тәпиләр белән юл тузанына чигү чигеп, Багражга кайтып киләбез.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Шуны гына ишетүгә, ата каз, нишләргә белмичә, әй тотына баскан урынында тыпыр-тыпыр биергә!* Г.Бәширов. *Имамлыгымны онытып, тыпыр-тыпыр биеп китәсем, очып йөрисем килә, табибә!* А.Тимергалин

**ТЫПЫ́Р-ТЫПЫР ИТҮ** *ф.* Биегәндәй еш-еш баскалау. *Читек кимә, итек ки! Егетләрчә итеп ки! Итек белән тыпыр-тыпыр, Тыпыр-тыпыр итеп куй!* М.Фәйзи. *Тыпыр-тыпыр итеп биеп китә мин сиңа әйтим, чапмас җиреңнән кул чабарсың!* М.Вәлиев

**ТЫПЫ́Р-ТЫПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **тыпыр-тыпыр итү**. *Ул, аяклары белән каз шикелле тыпыр-тыпыр килеп, Оттога кадалды.* Х.Камалов. *Тыпыр-тыпыр килүдән әле генә туктаган һәм ычкынып китәргә җаен гына көтеп торган җиңел, дәртле аяклар кузгалып куйды, йөрәкләр җилкенеп типте.* Н.Фәттах

**ТЫПЫРЧЫНУ** *ф.* 1) Борчылып, ризасызлык белдереп яки берәр җиргә ашкыну сәбәпле, аякларны бер урында тыпырдатып тору. *Әллә ни гөжләүгә, атларым тыпырчынуга уянып китсәм, кап-кара өермә өстемә килә.* Г.Хөсәенов. *Аяклары белән күпме генә тыпырчынмасын, башын ничаклы гына боргаламасын, гәүдәне әйләндерер өчен таяныр урын юк иде.* К.Кәримов

2) Берәр нәрсәдән яки кеше кулыннан ычкыну, котылу өчен, бар хәлгә тәне, кул-аягы белән тиз-тиз тәртипсез хәрәкәтләр ясау, бәргәләнү, чәбәләнү. *Заһидә ычкынырга тырышып тыпырчынды.* М.Маликова. *Кәҗәнең муеныннан сыйпаштырып иркәли генә башлаган иде, тегесе нигәдер тыпырчынып торып китте.* Г.Якупова

3) *күч.* Нинди дә булса бәйлелектән, уңайсыз хәлдән котылырга омтылу. *Кеше әле үзенең нәрсә көткәнен белми, ләкин күңеле өзгәләнә инде, тыпырчына.* М.Мәһдиев. *Камиләнең кая барып бәрелергә белмичә тыпырчынган тәне һәм җаны тынычланып китте.* Ф.Бәйрәмова

**Тыпырчына башлау** Тыпырчынырга тотыну. – *Юк, юк, – дип тыпырчына башлады ул, – дөресен укы!* М.Мәһдиев. *Бала инде ярыйсы ук тибенә башлаган иде, хәтта төннәрен йокларга да ирек бирми, мин бит дөньяга килергә җыенам, үзең күпме көттең, ә үзең йоклап ятасың, дигәндәй тыпырчына башлый.* М.Кәбиров

**Тыпырчына бирү** Бернигә дә карамый тыпырчыну, тыпырчынуын дәвам итү. *Шулай бер урында тыпырчына бирәм, тирә-якны да аера алмыйм.* К.Юлдаш. *Тр-р, хайван! Ул тыпырчына бирә, апа тегене астан кармалый.* З.Сөнгатуллина

**Тыпырчынып алу** Аз гына тыпырчыну. *Алай да күңеленең бер почмагында нindидер җылылык уянды, йөрәге тыпырчынып алды.* Ә.Сафиуллин. *Балык, мескен, бер-ике мәртәбә тыпырчынып алгач, тынып калды*. Р.Сәгъди

**Тыпырчынып карау** Тыпырчыну омтылышы ясау, тыпырчынырга тырышу. *Кыз тавышланып, тыпырчынып караса да ычкына алмады.* И.Хуҗин. *Әхмәт бәк тыпырчынып караган иде дә, үзен хөкүмәт даирәсенә керткәннәрен белгәч, ул да телен тешләде.* М.Әмирханов

**Тыпырчынып кую** Бер тапкыр тыпырчыну. *Моны күргәч, яр читендә йөзеп йөргән Балык тыпырчынып куйган. Әкият. – Чынмы? – дип, Идрисов сөенеченнән тезләнгән урынында тыпырчынып куйды.* Х.Камалов

**Тыпырчынып тору** Сөйләү моментында тыпырчыну; озак вакыт дәвамында тыпырчыну. *Кайчандыр минем дә тыпырчынып торган җаным бар иде.* И.Юзеев

**ТЫРАЙ** *и.* Агач яки берәр каты әйбернең кечерәк йомры кисәге. *Фоат тырайны тибеп җибәрде, башкалар аның артыннан йөгерде.* Ш.Маннур. *Тырай чокырга якын килә башласа, тиз генә читкә тибеп, тагын дәвам итте.* Казан утлары

◊ **Тырай тибү** Эшләмичә, вакытны бушка уздырып йөрү; эшсез йөрү, тик йөрү. *Мин әлеге әсәремне язып бетергәч, иркенләбрәк бер унбиш көн тырай тибеп йөргән, бушанып калган идем.* М.Мәһдиев. *Иң мөһиме: балаларның, үсмерләрнең урамда тырай тибеп йөрергә вакытлары калмаска тиеш.* Р.Миңнуллин

**ТЫРАКЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тыраклау**. Бер аяк белән сикертеп йөртү. *Сыңар аяк тыраклатып йөртәмени?* Г.Камал

2) *күч.* Куып җибәрү. *Гомәрова – үз дигәненә генә табынучы кире беткән зат, чөнниктән аны күптән тыраклатасы иде дә, тик анда Сирай бабайга ялгызына гына эшләве авыр булыр дип, теш кысып түзәбез, диде совхозның партоешма секретаре Григорий Леушин.* Г.Тавлин

**ТЫРАКЛА́У** *ф.* Бер аяк белән генә сикереп йөрү, бер аякка гына көч куеп йөрү; титаклау. *Агач бүкән шикелле төз катып авыз ачып торды да тиз арада өенә тыраклады.* Ә.Баян. *Бераздан тауны бер аягы белән шуып, бер*

*аягында тыраклап төшкән Сәетҗан да халык алдына килеп ауды.* В.Нуриев

**Тыраклый башлау** Тыракларга керешү. *Аңлатып бетергәнне дә көтмәде, тыраклый башлады карт.* Р.Вәлиев

**Тыраклый бирү** Бернигә дә карамый тыраклау. *Бабай безне көтеп тормады, тыраклый бирде, шулай да вакыт-вакыт артына карап алды үзе.* Ш.Маннур

**Тыраклый тору** Алданрак, берәр эш-хәлгә кадәр тыраклау. – *Син ял итеп ал, без тыраклый торыйк, – диде Сәлим, көтмәгәндә.* Кызыл таң

**ТЫРА́К-ТЫРАК** *рәв.* Сыңар яки кушаяклап еш-еш (сикерү тур.). *Мин китүгә, тырак-тырак сыңар аягында сикергәләп, «балаларым» янына Кесәми юнәлә ---.* Ф.Җамалетдинова. *Тырак-тырак сикерешкән бу сәер кошларга карап таң калды Гаяз.* Сабантуй

**ТЫРАНЧА** *и. зоол. к.* **минога**. *Тыранча личинкасы*

**ТЫРБАГАЙ** *с. диал.* Үзен башкалардан өстен санаучы, тәкәббер, мактанчык (кеше тур.). *Җирдә тора ике агай: Тарбагай да тырбагай.* Табышмак

**ТЫРБАГАЙЛЫК** *и. диал.* Тәкәбберлек, мактанчыклык. *Тырбагайлыкны өнәмәү*

**ТЫРБАЙЧЫК** *с. диал. к.* **тырбагай**. *Шундый ерак юлга, чит хәтле читкә, үзеңнең шул ике иптәш малаеңа да әйтми чыгып кит, имеш! «Тырбайчык!» диярләр, «астыртын ас икән!» дип сүгәрләр...* Ш.Маннур. *Шалапаймы, мактанчык-тырбайчык түгелме, үзен тотышы, килбәте күзгә кылчык кебек кадалмыймы?* Р.Газиз

**ТЫРБАЙЧЫКЛАНУ** *ф.* Мактану, үзен башкалардан өстен санау, кәпрәю. *Менә бит ул тырбайчыклансаң.* Р.Газиз. *Башта тырбайчыкланып, соңрак кикриге шиңгәннәр күп булды инде монда.* Кызыл таң

**ТЫРБАЙЧЫКЛЫК** *и. диал. к.* **тырбагайлык**. *Ә фортепианода ничек уйный!.. Дөрес, әзрәк тырбайчыклыгы бар барын.* Ш.Маннур

**ТЫРКЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тыркылдау**. *Тырмаларны тыркылдатып томырыла – түз генә.* З.Мансуров. *Кунаклар каршында куелачак концерт номерларын кабатладык, спортзалны бизәп плакатлар язып элдек, җырлар кабатлап, гармун тыркылдаттык.* Безнең гәҗит

**ТЫРКЫЛДА́У** *ф.* 1) Вак-вак адымнар белән кызу гына атлап бару, йөгерү; тырык-тырык итү. *Бөтен күршетирәләр үз «Жигули»ларында типтергәндә, нигә әле без генә җәяү тыркылдарга тиеш?* Ф.Яруллин. *Яңагыңа сыласа, кан әйләнешең яхшырыр, азрак акыл керер, теләсә кайсы матур аяклы, кыска итәкле артыннан тыркылдамассың, урам эте кебек.* Т.Галиуллин

2) Хәрәкәт иткәндә җиңелчә, еш-еш дыңгырдау. *Трактор тыркылдап урынында берничә тапкыр селкенде дә Гобәйдулла көчәнә-көчәнә күтәргән якка, алга ыргылды.* З.Зәйнуллин. *Тырык-тырык тыркылдап барган поезд тәгәрмәчләренең тавышына уралып, шундый уйлар буталды Виленның башында.* М.Маликова

3) Өзек-өзек тавышлар чыгарып эшләү, тыр-тыр, пык-пык итеп тору (машина, трактор һ.б.ш.). – *Монысы нәрсә тагын? – дим, мотоцикл тыркылдавын җиңәргә тырышып.* М.Яһудин. *Шул мәлдә ул, бәрән, сарык тавышларына кушылып, мотоцикл тыркылдаганны ишетте.* Ф.Җамалетдинова

4) Берәр уен коралында өзек-өзек көй чыгарып, аннан-моннан уйнау. *Гармун тыркылдаганы ишетелә*

5) *күч. диал.* Күп сөйләү, такылдау. *Тыркылдама әле, ишетелми*

**Тыркылдап тору** Сөйләү моментында тыркылдау; һаман, даими тыркылдау

**Тыркылдый башлау** Тыркылдарга тотыну. *Трактор, бульдозерлар тыркылдый башлагач та, күңеле тизрәк урамга тартты.* Ф.Җамалетдинова. *Билен биштән буып, авырлык белән генә тыркылдый башлады ул.* К.Кара

**Тыркылдый бирү** Тыркылдавын дәвам итү. *Без әле һаман тауга табан тыркылдый идек.* Р.Вәлиева

**ТЫРКЫН** *и. диал.* 1) Бер аяк белән генә сикереп, титаклап йөрү рәвеше. *Тыркын белән барып кына еракка китеп булмас.* Р.Вәлиев

2) Билгеле кагыйдәләр буенча сызыклар сызып, шул сызыклар арасында бер аяк белән генә сикереп йөреп таш тәгәрәтеш уены; сызык уены. *Җиргә сызып, без җәй буе тыркын уйный идек.* Сөембикә

**ТЫРКЫНЛА́У** *ф. диал. к.* **тыраклау**. *Менә шулай, әйбәт уйнаучы тыркынлап кына китә дә тагын әйләнеп чыга.* Н.Җиһаншин

**ТЫРМА** *и.* 1) Сөрелгән җирнең кантарларын ваклый, туфракны йомшарта торган авыл хуҗалыгы коралы. *Шундук тубалларын киеп алып, эшкәртелгән җиргә икесе ике яктан чәчеп чыгалар һәм тимер тырма белән орлыкны күмдереп тә куялар.* М.Хәсәнов. *Теләсә кайсы басуыгызга кереп китим мин сезнең – шунда ужым арасында тимер тырма таба алам.* М.Мәһдиев

2) Салам һәм печән җыяр өчен яки түтәлләрне йомшартыр өчен кулланыла торган озын саплы тешле эш коралы. *Кояш кыздыра башласа, тырма белән печән җыйды, чүмәлә салды.* З.Зәйнуллин. *Энесе Үсәр исә, кулына кечкенә тырма алып, әнисе казыган түтәлләрне тигезләргә керешә.* Ф.Зыятдинов

3) Сөрелгән җирне атка яки тракторга тагылган махсус корал белән йомшарту эше. – *Тырмага барырга вакыт, – дигән ачулы тавышы ишетелде.* Һ.Такташ. *Ай-һай, тырмага бер төшеп китсәк, тиз генә булыр микән ул иркен вакыт.* Н.Әхмәдиев

◊ **Тырманың сирәге яхшы** Мәҗлестә күп кеше тыгызланып утырганчы, халык азрак булганы уңайрак, дигәнне аңлата. *Тырманың сирәге яхшы.* К.Насыйри

**ТЫРМАВЫЧ** *и.* 1) Печән, салам җыю өчен, сәнәккә охшаш озын һәм бер якка кәкрәеп торган тешләре булган озын саплы авыл хуҗалыгы коралы. *Печән калын, тырмавычлар тиз тула, тибәбез күтәртү тимеренә, ярга йөгереп килгән дулкыннар кебек, печән тезмәләре кала.* Р.Газиз

2) Ярым әйләнә рәвешендә бөгелгән озын, нечкә тимер тешләре белән урылган, чабылган печәнне, саламны җыеп, өемнәргә салып бара торган бер күчәрле авыл хуҗалыгы машинасы. *Атлы тырмавыч. Ян тырмавыч. Асылма тырмавыч*

3) *сөйл.* Тырма, кул тырмасы. *Кече капка ачылганны ишеткәч, ул, кулына бәләкәй тырмавыч тотып, бакчасыннан чыкты.* А.Тимергалин. *Тырмавыч белән түтәлләрне яңадан тигезләде ул.* Н.Гыйматдинова

**ТЫРМАЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **тырмалау**. *Мин, аркам белән мичкәгә терәлеп утырган көе, юл читендәге яшел чирәмле канауларны, көрәнсу туфраклы тырмаланган басуларны күзәтеп, уйга талып барам.* Г.Галиев. *Сәрвия сменасын тапшырып ашыгып кайтканда, әтисе Мостафа, киртәгә таянып, тоташ тырмаланган бакчага таң калып карап тора иде.* М.Хуҗин

**ТЫРМАЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тырмалау**. *Иң элек ничәшәр сутыйлы бакчаны сукалата, тырмалата.* Г.Мөхәммәтҗанова. *Өендә тырма тартырдай кешесе булмаганнар күршегә акча төртеп тырмалатырга мәҗбүр.* З.Сәмигуллина

**ТЫРМАЛА́У** *ф.* 1) Җирне тырма белән йомшарту, тигезләү, сөргәннән соң калган кантарларны ваклау. *Зур галим булгач, иген игүдән бизсәң дә, тырма тырмалауларың сагынып сөйләргә хатирә булыр, ди.* М.Хуҗин. *Җир сөрергә, йөк сөйрәргә, тырмаларга, һичшиксез, ун-унике ел яраклы булачаклар әле алар.* З.Зәйнуллин

2) Тырма яки тырмавыч белән чабылган яки чәчелгән печәнне, саламны җыю яисә аралаштыру. *Зират өсләрен тырмаладым, тагын кемнеңдер бакчасын тырмаларга булыштым, мунча салганда, бүрәнәләр дә тарттырдым, урманга да барып кайткаладым.* Т.Миңнуллин

**Тырмалап бару** Шунда ук тырмалау, бар булганын рәттән тырмалау. *Әти алдан чәчеп бара, мин аның артыннан тырмалап барам.* Г.Бәширов. *Берәүләр сөрде, икенчеләре арттан тырмалап барды.* Н.Фәттах

**Тырмалап бетерү** Тырмалауны төгәлләү, барысын да тырмалау. *Бервакыт, инде эшләп арыганнан соң, укытучыбыз: «Менә шушы түтәлне казып, тырмалап бетерәсез дә кайтарам», – дигән шатлыклы хәбәрен игълан итте.* Э.Фатыйхова

**Тырмалап йөрү** Хәзер тырмалау белән мәшгуль булу. *Әти печән чапкан урынын тырмалап йөри иде.* Р.Вәлиев

**Тырмалап килү** Акрынлап, рәттән, эзлекле рәвештә тырмалау. --- *шунда ук ашлык чәчүче ир-атлар һәм алар артыннан җирне тырмалап килүче хатын-кызлар төркеме пәйда булуы да гаять табигый.* Ватаным Татарстан

**Тырмалап тору** Әле, сөйләү моментында тырмалау; даими тырмалау. *Җәен-кышын дигәндәй, вак тешле тырмалары белән җил тырмалап торган тау ярыкларында нинди үсемлек тамыр җибәрә алсын?* А.Хәсәнов

**Тырмалый башлау** Тырмаларга тотыну. *– Бүген үк, хәзер үк тырмалый башларга, чәчә башларга кирәк, – диде.* Н.Фәттах. *Мөбарәк 12–13 яшендә үк өлкәннәр белән беррәттән җир сөрә, тырма тырмалый башлый.* Ватаным Татарстан

**Тырмалый бирү** Бернигә дә карамый тырмалау. *Без килгәнне күрсә дә, эшен туктатмады, тырмалый бирде ул.* Р.Вәлиев

**Тырмалый тору** Булган берсен тырмалау; һаман тырмалау. *Эш җайга салынган безнең: абый баса тора, без тырмалый торабыз.* Казан утлары

**ТЫРМАНУ** *ф.* 1) Тырнаклар, тояклар һ.б.ш. очлы әйберләр белән нәрсәне дә булса эз калдырырлык итеп берөзлексез сыдыру, тырнау. --- *буыны ару-талуны белмәс Йосыф карт инде бетәште: биле бөкрәйгән саен, күз күреме тарайды, иелгән башы җирне һәм шул җирдә тырманган кешенең хәлсез аякларын гына күрде.* А.Гыйләҗев. *Ишегалдында тырманып тыныч кына йөргән кызыл әтәч, титибикәләрен ияртеп, абзарга ук кереп китә.* Н.Әхмәдиев

2) *күч. к.* **тырмашу** (*4 мәгъ.*). *Юккамы шул хәтле тырыша дип беләсең? Ул үзе өчен тырмана.* Ш.Камал

**Тырманып йөрү** Озак вакыт дәвамында тырману; хәзерге моментта тырману. *Алай да беренче айларда яңа фатирга кот кертү мәшәкатьләре, дүрт сутыйлы бакчада тырманып йөрүләр бар көчне алды, әйткәләшүләр зурга китмәде.* М.Маликова

**Тырманып тору** Сөйләү моментында тырману; әледән-әле тырману. *Тырманып торган тавыкларның бодайга бик исләре китмәде.* Р.Вәлиева

**ТЫРМАТУ** *ф. диал. к.* **тырмалау**. *Сез минем сабан сөреп, тырма тырматып йөргән җирләремне күрәсез.* Н.Нәҗми. *Кара, дымлы туфракка иген орлыклары сибә, аннары, җирне тырматып, аларны күмдереп чыга.* З.Мурсиев

**ТЫРМА́У** *ф. диал.* 1) *к.* **тырнау**. *Чардуганнар арасы тар, Альберт белән Кендекнең курткалары ертылып бетте, җитмәсә, агач ботаклары йөзне тырмый, пәрәвез авызга керә.* З.Мәхмүди. *Аунап, җир тырмап кычкырыр иде, халык карый.* Н.Кәримова

2) *к.* **тырмалау**. *Гүя аның бишекле күкрәгән кемдер арендага алган да шунда җир сөрә, тырмый, чәчә, ура, анда тамырдай каты куллары белән туфрак йомшарткандай итеп, үзенә кирәк максатларда файдалана, тик Сәдитнең үзен генә кертми иде.* А.Хәлим

**ТЫРМАЧЛА́У** *ф.* 1) Аркылы-торкылы тырнап бетерү, ермачлау; эзләр калдыру. *Кем язган аны [шигырьне] һәм ни өчен республика Верховный суды бинасындагы бүлмә диварына тырмачлаган.* Г.Тавлин

2) Җирне тупас итеп, аркылы-торкылы казу, аннан-моннан сөрү, эшкәртү, тырмалау. *Гайфи кабер өстенең үзе көрәге белән тырмачлаган җирләрен кабаланып күмәргә тотынды.* Г.Тавлин. *Трактор аламасы уйлап тапканчыга чаклы җир тырмачларга, утырып йөрергә яраган.* В.Имамов

**ТЫРМАЧЫ** *и.* Сөрелгән җирне атлы һ.б. тырма белән тигезләүче, гомумән тырма белән җир йомшартучы кеше. *Әй, тырмачы малайлар бригадасы, минем янга!* Т.Гыйззәт. *Минем шикелле тырмачы малайлар, атлары да җәһәтрәк атласын, күңеллерәк тә булсын дип, бераз барган саен, я кычкырып, я сызгырып җибәрәләр.* Г.Бәширов

**ТЫРМАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тырмау**. *Аннары чәч йолкыштылар, тырмаштылар һәм, тәтелдәшә-тәтел-*

*дәшә, яңакларын чәбәкләштеләр дә шуның белән вәссәлам.* Ф.Баттал. *Чәчләрен йолкышып, йөз-битләрен тырмашып котыра-тилерә кыйнашты алар.* Р.Сәгъди

2) Тырнаклар, тояклар һ.б.ш. очлы, тешле нәрсәләр белән казыну; тырнашу. *Капкынга эләккән җәнлек шикелле, үзен үзе белми тырмашты.* Х.Камалов. *Ирекнең болай да күкрәгеннән чыгарлык булып типкән йөрәге чатнап китте, ул кулы белән тырмашты, тыпырчынмакчы булды, бер генә мизгелдә үзен буган кешенең күлмәк якасына бармакларының керүен сизде, һәм ул аны аска тартып умырып төшерде.* Ф.Садриев

3) Тырнаклар, бармаклар белән ябышып, өскә яки алга таба үрмәләү, шуышу. *Ул көч-хәл белән тырмашып аягына басты, үрмәләп диярлек текә сукмак буйлап өскә менде.* А.Гыйләҗев. *Ләкин шулай булса да, торып басарга, баса алмаса, үрмәләп булса да тырмашырга, алга барырга кирәк иде.* Ф.Садриев

4) *күч.* Теләгенә ирешү өчен, бернинди каршылыкларга, авырлыкларга карамыйча, бик нык бирелеп, бар көчен куеп, тырышып эшләү. *Әлбәттә, дөнья мин сурәтләгәнчә үк ямьсез түгел, тырмашсаң, кояш төшмәгән җирдә дә яшәп була.* Т.Миңнуллин. *Күзебез күргәндә, колакларыбыз ишеткәндә, аякларыбыз йөреп торганда тырмашырбыз инде анысы. Бирешмәбез.* А.Хәсәнов

**Тырмаша башлау** Тырмашырга керешү. *Җан-фәрманга тыпырчыну да ярдәм итмәгәч, чынлап торып тешләшә, тырмаша ук башлады.* М.Хәсәнов. *Баш миенең бер почмагына кереп оялаган шомлы уй бераз гына онытылып тора да тагын тырмаша башлый, өскә чыга, аннары бөтен күңелне актарып ташлый.* Р.Вәлиев

**Тырмаша бирү** Бернигә дә карамый тырмашу, тырмашуын дәвам итү. *Бернинди киенлыкларга да карамый тырмаша бирде ул.* Сөембикә

**Тырмаша тору** Озак вакыт дәвамында тырмашу; сөйләү моментында тырмашу. *Тырмашабыз инде, тырмаша торгач, картаеп та барабыз инде.* Н.Нәҗми

**ТЫРНАВЫЧ** *и. диал. к.* **тырмавыч** (*1, 3 мәгъ.*). *Егет төнлә кырынрак сөялеп куелган тырнавыч тешенә ялгыш барып баса да, тырнавыч сабы моның маңгаена китереп куя.* Г.Толымбай. *Без дә, алардан аерылып тормас өчен, куак агачыннан ике җәпле тырнавыч сыман нәрсә хәстәрләп, иңнәргә салдык.* Ф.Хуҗин

**ТЫРНАК** *и.* 1) Кеше бармакларының очында үсә торган каты мөгез катлау. *Тырнаклары сынып, сыдырылып беткән икән картның, сул кулының ике бармагын түгәрәк пычкы кыеп төшергән икән.* А.Гыйләҗев. *Тырнак төпләрендәге дегет, оекбаштагы арпа кылчыклары, бирчәйгән уч төпләре – кичәге тормышның истәлеге әнә шулар.* М.Мәһдиев

2) Күп кенә хайван яки кош бармакларының очындагы очлы, кәкре мөгез үсенте. *Капка-койма буйларындагы тузанлы баганаларга үрмәли-үрмәли, мәчеләр тырнак батырдылар, кичке якта өере-өере белән каргалар кычкырышып йөрде, зерәгә генә этләр өргәләп алды.* М.Мәһдиев. *Тилгән тырнакларын җәеп бәпкәгә үрелүе булды, көчек гәүдәсе белән бәпкәне каплады.* Р.Батулла

3) Чана табаны белән үрәчәсен тоташтыра торган тешләрнең берсе; *русчасы*: **копыл**. *Тайгак бозлы көпчәк тырнаклары арасында өзлексез чайкалып торган суык судан өс-башыбыз, гипслаган кебек, бөгелмәс булып катты, кул-аяк күшеегп бетте.* С.Сабиров.

4) Тәгәрмәч тугымын бүкәнгә беркетә торган агачларның берсе; киги; *русчасы:* **спица**. *[Имән:] Чөнки арба тәгәрмәчләренең тырнакларын, чананың табаннарын миннән ясыйлар.* Н.Антонова

5) Бер баш сарымсакның аерым бүлемтеге. --- *әрчеп-нитеп тормыйча гына, авызына бер тырнак сарымсак ыргытты.* Ф.Садриев. *Сабыегыз балалар бакчасына йөрсә, киндер-сюрприз савытына җеп тагып, аны берничә урыннан тишеп, шуңа бер-ике тырнак сарымсак салып, баланың муенына асып җибәрергә мөмкин.* Кызыл таң

6) *махс.* Баганаларга, текә тауга менү өчен, аяк киеме өстеннән киелә торган һәм эчкә бөгелгән ягына тешләр ясалган урак сыман тимер җайланма; *русчасы*: **когти**. *Шул вакыт минем тизрәк үсәсем, җилкәләремә тырнаклар асып, авыл урамнарыннан үтәсем, ак «чыбык»ларны зәңгәр һавага сузып, өйләрне өйләргә тоташтырасым килде.* Ф.Яруллин. *Аягына озын тимер тырнаклар тагып, багана башларына менеп йөрде.* Р.Фәизов

7) Тауларда, таш кыяларда яки юеш үләндә йөргәндә таеп егылмас өчен, аяк киеменең табанына беркетелә торган ыргак сыман җайланма; *русчасы*: **шип**. *Кайгырма, Гозәир бабай, минем аякларда хәзер корыч тырнаклар.* Т.Гыйззәт

8) Салам түбә өстенә аркылы яткырылган колгаларны тотып торыр өчен, буй колгаларга беркетелгән кыска агач казык // Түбәдә су улагы беркетелә торган агач казык

9) Берәр әйберне тотып тору өчен, металл яки башка нәрсәдән ясалган теш. *Йөзекнең кашы төшкән, кашны тотып торган тырнаклар эчкә яньчелеп кергәннәр.* Ә.Фәйзи

10) *лингв.* Текстта туры сөйләмне, цитаталарны, аерым кайбер предмет исемнәрен, шулай ук шартлы һәм ироенияле мәгънәдә кулланылган сүзләрне һәм гыйбарәләрне аера торган парлы тыныш билгесе (‘ ’, " яки « », ешрак куштырнак формасында кулланыла). *Язуда мондый сүзләр тырнаклар эченә алып күрсәтелә.* Г.Алпаров. *Тырнак эченә алып язылган «кыз» сүзе «кыз түгел» дигән кире мәгънәдә, мыскыл рәвешендә генә әйтелергә һәм язылырга мөмкин.* Н.Исәнбәт

11) *күч.* **тырнагы** *тарт. форм.* Рәхимсез хакимлек, бәйлелек. *Ул укыганда, тамакка нәфрәт төере тыгыла, шагыйрьләрне фашизм тырнагыннан азат итәр өчен, бөтен Җир шарында чаң кагасы килә.* Р.Мостафин. *Шушы минутларда улым үлем белән тартышып ятадыр да, мин генә аны әҗәл тырнагыннан тартып алып калырмын кебек.* В.Нуриев

◊ **Тырнагына да тормау** *к.* **кисеп ташлаган тырнагына да тормау**. *Җәләй Фатыйманың салпы ягына*

*салам кыстыруны дәвам иттерде: – Мулла кызы Сания синең тырнагыңа да тормый, махы бирдең...* Ә.Галиев. *Тырнагына да тормас кеше белән сүзгә килгән бит.* Г.Галиев. **Тырнагын да тидертмәү** Кемне яки нәрсәне дә булса икенче берәү һөҗүменнән, рәнҗетүеннән саклау. *Туган анам – сөйгән Ватаныма Тырнагын да [фашистның] тидертмәм.* М.Җәлил. **Тырнак астына алу** 1) Икенче берәүне яки җәмгыятьне үзенә тулысынча буйсындыру, бәйле итү. *Буржуйларга безне бетерү кирәк, Сугыш кирәк буржуй халкына, Базар кирәк, Безнең ирекле илне Алу кирәк тырнак астына.* Һ.Такташ; 2) Бетерү, юк итү. **Тырнак астында** Кемнең дә булса көчле хакимлеге, контроле, басымы астында булу. *Франко режимы илне тимер тырнак астында тоткан дәвердә Гарсиа Лорканың китапларына үз илендә дөнья күрергә насыйп булмый.* М.Галиев. **Тырнак астыннан кер табу** *к.* **тырнак астыннан кер эзләү**. *Сезгә тагын бер үтенечем бар: бу хат турында берүк Хөснуллага сиздерә күрмәгез; тырнак астыннан кер тапкандай, аңа тагын бәйләнергә, авызынборынын турсайтып, тузынып йөрергә сылтау булмасын иде.* С.Сабиров. *Эзләсәң, тырнак астыннан да кер табыла.* Л.Ихсанова. **Тырнак астыннан кер эзләү** Берәр кешенең булмаган яки вак-төяк гаепләрен күпертеп күрсәтү, бәйләнергә сылтау табарга тырышу. *Арада, тырнак астыннан кер эзләп йөрмиме бу, дип, профессорга шикләнеп һәм өнәмичә караучылар да булды.* М.Маликова. *Тырнак астыннан кер эзләү олы вакыйгалардан читләштерә.* Т.Галиуллин. **Тырнак басарлык урын булмау** *к.* **инә төртерлек урын булмау**. *Кәнсәләрнең югарылы-түбәнле өч киштәсендә тырнак басарлык буш урын юк.* Ш.Камал. **Тырнак батыру** Һөҗүм итү. *Ирек үзенең җилкәләренә баскан ялганның тырнак батыруын сизеп куйгандай булды.* Ф.Садриев. *Җиңел булганмы ул, илебезне, аңа фашист тырнак батыргач, солдат киеменә киендерү?!* Р.Харис. **Тырнак башы хәтле (кадәр)** *к.* **тырнак очы кадәр**. **Тырнак белән дә чиерттермәү (чиертергә ирек бирмәү)** Кемне дә булса кыйнарга, кыерсытырга, рәнҗетергә мөмкинлек бирмәү. *Ул авыл малайларын куркытып торса торды, әмма энесенә тырнак белән дә чиерттермәде.* Казан утлары. **Тырнак белән дә чиертмәү** Кемгә дә булса сукмау, зыян китермәү, аны кыерсытмау, гомумән аңа кагылмау. *Юк, әгәр шулай дип кычкырсаң, тырнак белән чиертәчәк түгелләр.* Г.Бәширов. *Тырнак белән дә чиртмәм, ышанысыз, Шәрифҗан әфәнде, кем әйтмешли, өрмәгән урынга да утыртмам.* И.Юзеев. **Тырнак кабарту** Кемгә дә булса ачулану, аңа каршы сүз әйтергә җыену. *Тырнакларын кабарткан бу көяз ханымны күргәч, ул югалып калды.* Кызыл таң. **Тырнак карасы кадәр** *к.* **тырнак очы кадәр**. *Юк инде, булмаса булмас – ул аңа барыбер тырнак карасы кадәр дә хыянәт итәргә тиеш түгел, күңеле белән дә, уе белән дә хыянәт итәргә тиеш түгел!* Н.Фәттах. **Тырнак күрсәтү** Усал табигатен, үзендә көч барлыгын һәм кирәк очракта көч куллanудан да тартынмаячагын сиздерү; куркыту. *Тырнак күрсәтеп, бөтен авыл яшьләрен куркытып яшәргә өйрәнгән инде ул шулай.* Ш.Маннур. **Тырнак очы белән дә кагылмау** Үпкәләтмәү, тимәү; намусын пычратмау. *Бу егет миңа тырнак очы белән дә кагылмады, гомер аяк басмаган таныш түгел аулак бер урамда ялгызымны бастырды да калдырды.* Р.Габделхакова. *Карчык, югарыга төбәлеп, аһ-зар килде: – Ирегем бит тырнак очы белән дә кагылмаган!* Р.Камал. **Тырнак очы белән дә тимәү** *к.* **тырнак очы белән дә кагылмау**. *Тырнак очы белән дә тимәдем!* З.Мәхмүди. *Эчте Капитан, бәйрәмнәрдә «мин кавалерист» дип күкрәк төйде, ә өйдә мәче кебек: авызыннан сүзе чыкмый, Яңылга да тырнак очы белән дә тигәне юк.* Р.Камал. **Тырнак очы белән дә чиертмәү** *к.* **тырнак очы белән дә кагылмау**. *Зөлфия, үзең беләсең, гомергә сиңа авыр сүз әйткәнем, тырнак очы белән чиерткәнем юк.* И.Юзеев. **Тырнак очы кадәр (кадәрле, хәтле)** 1) Аз гына да; бөтенләй. *Тырнак очы кадәр гаебем булмаса да, бәладән башаяк, диде.* Г.Галиев; 2) Бик кечкенә, бик аз. *«Бәлки әле, чыннан да, Сария янындагы төнге кунак Хатыйп булмагандыр», – дигән тырнак очы кадәрле генә бер өмет кисәге, таң алдыннан таралган сыек томан кебек, эреп юкка чыкты.* Ш.Җиһангирова. **Тырнак пычрату** *к.* **кул пычрату**. *Андый маңка Куйлар илә нигә тырнак пычратырга кирәк!* Г.Тукай. **Тырнак та тидермәү** *к.* **тырнак белән дә чиертмәү**. *Кызыгызга тырнак та тидергәнем юк, әллә кемнәр сүзенә ышанып йөрмәгез.* Сөембикә. **Тырнак тирләтү** Бик нык оялту, оятка калдыру. *Кыланышлары белән тырнак тирләтәләр.* К.Тинчурин. *Бу «роман»ның тырнак тирләткеч тәфсыйләтен --- башыннан кичергәндә, дөньяда күпне күргән, картая башлаган доктор Хөсәен унсигез яшьлек яшь егет шикелле кызарды.* Г.Рәхим. **Тырнак хәтле** *к.* **тырнак очы кадәр**. *Сезнең хакта тырнак хәтле дә яман уйда түгелмен, Гайшә ханым!* Г.Кутуй. *Берәү урманда тычкан уты табып учына куя да: «Тырнак хәтле генә мәхлук, кара син аны ничек яктырта!» [ди].* Ш.Галиев

**ТЫРНАКГӨЛ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан өлгергән орлыклары кош тырнагына охшашлы, әфлисун сары төстә чәчәк ата торган бакча гөле; пәйгамбәр тырнагы; *русчасы:* **ноготки**. *Нәркис, тырнакгөл, роза, хризантемаларны аерым утыртырга кирәк, чөнки алар янындагы башка чәчәкләр сулырга мөмкин.* Матур буласың килсә. *Ромашка, шалфей яки тырнакгөл төнәтмәсенең ярдәме тиз сизелер.* Кызыл таң

**ТЫРНАКГӨ́ЛЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Ялгыз яки чәчәк төркемендә урнашкан чәчәкле, тартмачык яки бер өлешле орлыкларга таркала торган җимешле йолдызсыман төкчәләр белән капланган үсемлекләрне берләштерә торган семьялык. *Тырнакгөлчәләрдән мамык түбен (жмых) ашап агуланган хайваннарның да сөтләре агулы булырга мөмкин.* Агулы үсемлекләр

**ТЫРНАКЛА́У** *ф. сөйл. кбтл. ф. к.* **тырнау** (*7 мәгъ.*). *Мостафаның ка-*

*рандаш белән генә тырнаклаган доклад тезислары бар иде.* Ш.Камал. *Соңгы җырын Муса шырпы белән сабын өсләренә тырнаклый.* С.Баттал

**ТЫРНАКЛЫ** *с.* 1) Тырнагы булган; билгеле сыйфаттагы яки сандагы тырнакка ия булган. *Фирдүс сары тырнаклы каты бармаклары белән зәңгәр язулы «Беломор» кабын ертты, папирос алып, җәрәхәтле иреннәре арасына тыкты, аннары кабызып, олы бүлмәгә керде.* М.Маликова. *Башка рептилияләрнең икешәр пар очлыклары һәм һәр очлыкта тырнаклы бишәр бармагы бар.* Т.Шакирова

2) *күч.* Усал, явыз. *Тырнаклы адәм түрәне кол итәр.* Мәкаль. *Әмма киребеткән нәрсә, теле тырнаклы, һич игә китерә торган түгел.* Ш.Маннур

**ТЫРНАКЛЫ́ ГӨЛ** *и. бот. к.* **тырнакгөл**. *Күп, бик күп анда чәчәкләр: йолдыз чәчәкләре, тырнаклы гөлләр, георгиннар.* Г.Мөхәммәтшин

**ТЫРНА́К-ТЫРНАК** *с.* Тырнаклар зурлыгындагы, тырнакларга охшаш. *Өстемә лә кигән күлмәгемнең Тырнак-тырнак агы бар.* Җыр. *Әле дә күз алдымда: тырнак-тырнак бизәкләр төшкән иде ул китапның тышында.* Р.Вәлиева

**ТЫРНА́К УТЫ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан гади, йолдызсыман төкчәләр белән капланган һәм гадәттә сары чәчәк ата торган күпьеллык үлән үсемлек; карчыга үләне; *русчасы:* **ястребинка**

**ТЫРНАНУ** *ф. кайт. юн. к.* **тырнау**. *Ул юлның әле бер ягындагы куаклар арасына, әле икенче ягындагысына керәп-кереп китә, иснәнә, аяклары белән җирдә тырнана да кабат юлга чыга, туктап, Данил белән Диләнең аңа якын килгәнен көтеп тора.* З.Мәхмүди. *Бакча башындагы тиреслектә тырнанучы әтәч-тавык халкы да каралтыкурага таба йөгерә-кайта башлады.* Р.Батулла

**Тырнана башлау** Тырнанырга керешү. *Чуар тавык тагын шул урынга барып тырнана башлады.* Р.Вәлиева

**Тырнанып тору** Хәзерге вакытта тырнану. *Песи диванның нәкъ син утырырга ярата торган җирендә тырнанып тора иде, мине күргә үк диван артына кереп качты.* Сөембикә

**ТЫРНА́У** *ф.* 1) Тырнак яки тояк очын батырып, берәр йомшак нәрсәне сыдыру, ерту, җәрәхәтләү. *Кисәктән бер тавыш ишетсә, --- урынында утырып тора алмай, тешләрен шыкырдата, өстендәге киемнәрен ерта, тырнаклары белән аны тырный, моны тырный.* К.Насыйри. *Ялгыз калган ат җирне тырный, мин генә түгел, ялгыз калгач, ул да пошына, күрәсең.* Д.Бүләков

2) Теләсә нинди очлы яки каты нәрсә белән сыдырып, эз калдыру. *Ташның бер кырына очлы тимер белән тырнап, «Кәлимулла» дип язылган.* А.Гыйләҗев. *Карчыкларның сихер алачыгы ишегенә тырнап сызылган тамганың зурайтылган сурәте төшерелгән бит бу аланга!* Г.Гыйльманов

3) Нинди дә булса каты нәрсә сыдырып, тәнне авырттыру, эзләр калдыру. *Малайның битен куаклар тырный, бер ботинкасы төшеп калгач, ул икенчесен дә салып ыргыта.* А.Тимергалин. *Мидхәт Рамиләнең зәңгәр бизәкле фланель күлмәген сабынлап ышкыганда, түшендәге җөй учын тырнады.* М.Маликова

4) *күч.* *Күңел, шик, йөрәк* сүзләре белән килгәндә, «өзлексез борчу, тынычсызлау, газаплау» мәгънәсен белдерә. *Үзенең инде шулай йөгереп йөрер көннәренең мәңге кайтмаслык булып ерак калулары аның йөрәген тырный.* А.Алиш. *Үзебезнең Бишмунча авылында мәчет манарасын кистереп йөрүем исемә төшеп, җанны тырнады.* Х.Камалов

5) *күч. сөйл.* Буразна яру, җирне сукалау, сөрү, эшкәртү. *Бер-берсенә янәшә китереп тагылган тырмалар, очлы тешләре белән кылган үскән каты җир өстен тырнап бардылар да, сөрелгән җиргә җитеп, кинәт кенә йомшак кара туфракка чумдылар.* Н.Фәттах. *Яңа гына җир тырнап үткән трактор эзеннән башка бернәрсә дә сизелми.* Д.Бүләков

6) *диал. к.* **тырмалау**. *[Авыл халкына], күбесенчә, даланы айкап, коры үлән тырнарга һәм әрем чабарга туры килде.* Ш.Камал

7) *күч. сөйл.* Ашыгып, теләр-теләмәс кенә, аннан-моннан, танымаслык итеп язу, сызгалау. *Менә ул акрын гына кулын күтәрде, чыбык очы белән озаклап, теләр-теләмәс кенә мин язган сүзләрне бозды, гафу ит, дип ике сүз тырнады да, чыбыгын ташлап, өйгә кереп китте.* Л.Ихсанова. *Хәлим актыккы көчен җыеп торып утырды, үлә-нитә калса, кәфенлек урынына кирәк булыр дип, түшәктәге ак җәймәне җыеп топты, аннары, ишек төбендәге соскыдан бер шакмак күмер алып, стенага язу тырнады: «Майя, миндә үлем авыруы».* Г.Гыйльманов

**Тырнап алу** Бер тапкыр тырнау. *Шулхәтле мавыгып китәләр: сүзгә килеп, оныкбабасының кулын тырнап ала, бабай оныкның ботын чеметә.* Ш.Галиев. *Көнләшмәсәм дә, эчемне нәрсәдер тырнап алды: шул чебешнең нәрсәсенә исе китте?* Г.Якупова

**Тырнап бару** Рәттән, шунда ук тырнау, озакка сузмыйча тырнау. *Энем дә бик ярдәм итте бүген: без чапкан җирләрне тырнап барды.* Р.Вәлиев

**Тырнап бетерү** Барысын да тырнап чыгу; нык тырнау. *Энәләрең белән бөтен җиһазыбызны тырнап бетерәсең!* Л.Закирова. *Тавыклар безнең ишегалдында йөреп, бар җирнең астын өскә китереп тырнап бетерде.* Ф.Йосыпов

**Тырнап карау** Берәр максат белән тырнау. *Имеш, Наполеон урыслар турында болай әйткән: «Һәр урыс кешесен бераз тырнап карасаң, астыннан татар килеп чыгар», – дигән.* Р.Батулла. *Тырнап карыйм – таш кебек!* М.Вәлиев

**Тырнап кую** Кисәк кенә тырнау. *Кинәт йөрәгем авыртып кысылды, үкенүдерме, икеләнүдерме – белмим нидер – бәгъремне тырнап куйды.* Ә.Еники. *Соңгы көннәрдә Зөһрә белән икебезнең арада барлыкка килгән салкынлык тагын эчне тырнап куйды.* Н.Фәттах

**Тырнап ташлау** Тиз генә тырнау. – *Печән чапкан урынны гына тырнап ташла да, дусларың янына чыгарсың, – диде әти.* Ш.Маннур

**Тырнап тору** Сөйләү моментында тырнау; даими тырнау. *Зарары юк*

*микән ул каралы савытның, шул гына эчемне тырнап тора.* Н.Фәттах. *Сумкам юклыгы күңелемне гел тырнап тора.* Ш.Җиһангирова

**Тырный башлау** Тырнарга керешү. *Ләкин бу курку карак мәче шикелле посып кына килә дә күңелне тырный башлый.* Л.Ихсанова. *Пират, көндәшенең үз улы икәнен күреп, тояклары белән җирне тырный башлады.* Р.Сәгъди

**ТЫРНАШТЫРУ** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **тырнау**. *Малай әтисенең кабере өстенә капланып яткан, йөзе бер яктан күренеп тора, теле каралып авыз эченнән салынып чыккан, кул бармаклары зәңгәр-фиолет төсендә янган, бер аягыннан ботинкасы салынган, ә икенчесе белән, тырнаштырыптыр инде, кабер өстеннән байтак чирәм, кәс, кызыл балчык ишкән.* М.Мәһдиев. *Малай кыбырсый, энисенең күкрәк турын тырнаштыра, мөгаен, тамагы ачкан иде.* М.Маликова

2) Тиз-тиз генә тырнау; аннан-моннан гына тырнау. *Безнең территория бу, дип, башын күтәрми генә, Мортазаның аяк очын себеркесе белән тырнаштырды ул.* М.Маликова. *Аерым кабер казырлык хәлләре булмагач, туң җирне тырнаштырып, өчесен бер кабергә салып кайттылар.* Ф.Бәйрәмова

**Тырнаштыра башлау** Тырнаштырырга тотыну. *Шуннан, нәрсә икән соң бу дип, таягым белән читләрен тырнаштыра башладым.* Ә.Еники. *Мин үзем сөялгән бүлмә тактасын тырнаштыра башладым.* Г.Бәширов

**Тырнаштырып тору** Әле, сөйләү моментында тырнаштыру. *Әнә шул шөбһәләнү аны гелән бимазалап, йөрәк тирәсен тырнаштырып торды, аңа тынгы бирмәде.* Р.Кәрами

**ТЫРНАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **тырнау**. *Акбүз атларга атланган ак киемле төркемнән берничә адым алдарак, төрлечә кыланып, ихахайлап, елап, тырнашып, юл буенча нindидер карачкылар кыймылдый иде.* Н.Фәттах

2) *к.* **тырмашу** (*2 мәгъ.*). *Карый үзенең канлы аягына, Селкетмәкче була... юк... авыр: Кемне көтеп ятсын [Аникин] бу ят җирдә, Тырнашыпмы алга кузгалыр.* Ф.Кәрим

3) *күч.* Авыр эшне үтәргә тырышу, маташу, азаплану

**Тырнаша башлау** Тырнашырга керешү. *Эчтә мәчеләр тырнаша башласа да, үтә чыккан гамьсез кылангган булам.* Р.Төхфәтуллин. *Карттан ишеткән бу хәбәр аны дәртләндереп җибәрде, аңа яңадан көрәш рухы әйләнеп кайтты, ул тагы яшәү өчен тырнаша башлады.* Ф.Бәйрәмова

**Тырнаша бирү** Бернигә дә карамый тырнашу

**Тырнашып алу** Бераз гына тырнашу. *Эш чәч йолкышуга ук барып җитмәде, шулай да чеметешеп, тырнашып алырга өлгерделәр.* И.Гази

**ТЫРПА** *с.* 1) Тырпаеп, кабарып торган. *Нургаянның үзе шикелле елтыр күзле, тырпа чәчле малайлары ул җирне яхшылап тигезләделәр, ком китереп җәйделәр.* Р.Фәизов. – *Тырпа мыегыңны ерактан ук күреп алдым, – диде Сәвия, егете якынлашкач.* Кызыл таң

2) *күч.* Тупас, дорфа табигатьле, кешегә ачы, чәнчүле сүз әйтергә ярата торган. *Тырпа җитәкче*

**ТЫРПАГАЙ** *с. сөйл. к.* **тырпа** (*2 мәгъ.*). *Елмаеп әйтсәм, ялагай булам, Турсаеп әйтсәм, тырпагай булам.* Мәкаль

**ТЫРПАЙ** *с. диал.* Тырпайган. *Төртке, тырпай мыек борын астында гына калдырылган.* А.Расих. *Зөлкәрам бер малайны җирән чәчле, мул сипкелле, нәзек, озын итеп төшерде, икенчесен юантык һәм тәбәнәк гәүдәле, квадрат йөзле, калын кара кашлы итеп иҗат итте, ә өченчесе, әйдә, озын борынлы, тырпай колаклы булсын.* З.Мурсиев

**ТЫРПАЙТУ** *ф.* 1) Бармак, кул, чәч һ.б.ш.ны берәр якка аерып турайту. – *Әле без никах укыттырмаган ич! – дип терсәкләрен тырпайтты.* Т.Әйди. *Офицер да аның сокланг ыч күз карашын сизде, ахры: «Фрегат!» – диде ул горур тавыш белән һәм баш бармагын өскә тырпайтты.* И.Хуҗин

2) Берәр нәрсә эченнән, өстеннән һ.б. бүлтәйтеп, кабартып чыгару. *Рәүф үзенекеләрне бер-берсеннән егермешәр адым калдырып тезде, чалбар кесәсен тырпайтыбрак торган борынгы сәгатен чыгарып, Гәүһәр апаныкы белән чагыштырды.* А.Тимергалин. --- *тәбәнәк коймалы ишегалларында чем кара мазутка буялып, кайсы кайда чәчелеп яткан эреле-ваклы болтлар, кырлысырлы гайкалар, кар эченнән кәкре башын тырпайткан трактор детальләре шул хакта сөйли.* А.Вергазов

**Тырпайта бирү** Тырпайтуын дәвам итү. – *Сезнең кебек куркып, вакланып тормас идем, – диде Идрисов, энәләрен һаман тырпайта биреп.* Х.Камалов

**Тырпайтып җибәрү** Бераз гына тырпайту; тиз генә тырпайту. *Рельс юлларын нәзегәйтеп-тарайтып йота сымак та, киресенчә, зур дөньяга мыек сымак тырпайтып җибәргән төсле.* С.Шәрипов

**Тырпайтып кую** Тырпайган хәлгә китерү. *Әмма кара айгыр әкәмәт сизгер, янына бара башласаң, колакларын тырпайтып куя, күзләре фонарь кебек яна башлый, танау тишекләре киңәя.* Ф.Яруллин. *Рус теле укытучысы гадәтенчә өстенә ак кофта, кара юбка кигән, кыска, сыек саргылт чәчләрен күпертеп, тырпайтып куйган иде.* Н.Фәттах

**Тырпайтып тору** Озак вакыт дәвамында тырпайту. *Өрми торган эт кебек үзләре килеп тешләгәнче, аларның нәрсәгә бәйләнәсен алдан күреп, мәче кебек, ис сизүче мыегыңны гел тырпайтып торырга туры килә.* Т.Галиуллин. *Ә мин, үртәп-үртәп, алтын бармакларымны тырпайтып тордым.* Ә.Галиева

**ТЫРПАЮ** *ф. сөйл.* 1) Тураеп төрле якка чыгып, күтәрелеп тору, үрә тору (чәч, йон һ.б.ш. тур.). *Минем тәннәремә каз ите чыга, чәчләрем тырпая.* М.Мәһдиев. *Мостафинның терсәге тырпайды, ул пистолетын тартып чыгарды.* Х.Камалов. *Муены тырпая, гәүдәсе турая, йөзенә алсулык йөгерә, күзләрендә очкын кабына.* М.Әмирханов

2) Берәр нәрсә өстеннән ботак сыман булып чыгып, күтәрелеп тору (каты әйберләр тур.). *Аркасыннан һаман да шул мылтыгының көпшәсе тырпайган.* А.Хәлим. – *Беркөнне минем агач фатирда булганыең бит әле, –*

*дип сөйләп китте Акмал. – Идәндәге тырпайган кадакка эләгеп, түбәтәең җыртылганые.* Л.Лерон

3) *күч.* Башкалар алдында үзен эре күрсәтергә тырышу, кәпрәю, тәкәбберләнү; һавалану. *Шулай итеп, Чуракай карак айлар буе ат өстендә тасыраеп, тырпаеп йөри башлады.* Р.Батулла

4) *күч.* Берәр нәрсәгә бик ачулану; үпкәләү; турсаю. *Чөнки бит ул үзе дә әнә бер генә сүз дә әйтми, бөтен ачык җирен яшергән керпе шикелле йомылып, тырпаеп тик утыра.* Ә.Еники. *[Мәгъсүм:] Ә менә шул турыда сөйли башладыңмы – бөтенләй тырпая.* Р.Ишморат

**Тырпаеп калу** Нәрсәдән дә булса тырпайган хәлгә килеп, шуны саклау. *Шул ук таушалган киемнәрдән, сәгать чылбыры гына юк та күлмәк төймәләрен ялгыш каптырган, якасы тырпаеп калган.* А.Гыйләҗев. *Тырпаеп калган тимерчыбык кисәге кыска булып чыкты, яңадан бәйләп куярга җитмәде.* А.Вергазов

**Тырпаеп китү** Кинәт тырпаю. *Ачулыга сәҗдә кылсаң, ул тагы тырпаеп китәр.* Әйтем. *Укытучысы да мактагач, канатлары тырпаеп киткән Шәрхемулла район гәҗитенә бара торган сукмакны да белеп алды.* Ф.Баттал

**Тырпаеп тору** Озак вакыт дәвамында тырпаю; хәзер тырпайган хәлдә булу. *Гөлфинур, стенага борылып, тырпаеп торган мүк кисәген бармагы белән ике арага төрткәли-төрткәли әйтеп куйды.* А.Вергазов

**Тырпаеп утыру** *к.* **тырпаеп тору**. *Ул үзенең булачак йортының сырлы шифер түбәсен күрде, тырпаеп утырган кызыл моржасын күрде, бакча эчендә алмалар, карлыганнар күрде.* Н.Фәттах. *Чулман уртасында тырпаеп утырган утрау үткен хәнҗәрдән бер дә ким түгел.* В.Имамов

**Тырпая башлау** Тырпаерга тотыну. *Тургановның, аны күрүгә, йөзе үзгәреп китте, иреннәре калтырый, бөләкләре тырпая башлады.* Х.Камалов. *Лесникның елмаю уңаена яткан мыегы тырпая башлады.* М.Галиев

**Тырпая төшү** Бераз тырпаю; тагын да тырпаю. *Колаклары тагын да тырпая төште.* Т.Галиуллин. *Яңаклары чокыраеп баткан, сөякләре тырпая төшкән.* Н.Хәсәнов

**ТЫРПЫЛДА́У** *ф.* 1) Тик кенә тора алмау, бәргәләнү, китәргә ашкынып, кыбырсып, ярсып тору. *Тере балык нинди чая, ничек тырпылдый!* Ш.Галиев

2) Көчле тәэсир, кичерештән ярсып тибү (йөрәк тур.). *Әйтерсең лә Госманның тырпылдаган йөрәгенә алмаз хәнҗәр кададылар, ул, тетрәнеп һәм калтыранып, ишекне ачып җибәрде.* И.Салахов

3) Ашыгу, кабалану, түземсезләнү. *Пенсиягә китәр вакытың якынлашканда, әллә ни тырпылдар чама юк шул.* Ф.Садриев. *– Сез, иптәш Вәлиев, кыз-катын төгел бит, нигә шылай тырпылдыйсыз? Нигә пожар чыккандай кабаланасыз? – дип, тезгенемнән тартып куйды.* В.Нуруллин

4) Нинди дә булса борчулы уйлар, хисләр һ.б. тәэсирендә тынычсыз булу. *Таңга кадәр тырпылдап ятты хатын, таң алдыннан соравын тагын кабатлады.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Ашкыну. *Аның хыялы күкләргә сыя алмыйча тырпылдый, һәм аның күз алдындагы Нәҗип шәүләсен, көтмәгәндә, Сабит абыйсы алыштыра.* А.Гыйләҗев. *Җан тырпылдый һаман күкрәкләрдә, көнләшәбез очкан кошлардан.* Х.Гайнетдинов

**Тырпылдап алу** Бер тапкыр тырпылдау; бераз гына тырпылдау. *Тырпылдап алды да тынды күбәләк.* Ш.Маннур

**Тырпылдап кую** Тырпылдаган бер хәрәкәт ясау. *Йөрәге тырпылдап куйды егетнең.* А.Гыйләҗев. *Хәер, менә бу җир белән мәшәләнә башлагач, күңеле тырпылдап куйды картның, ләкин ул белә: бу инде күкрәп утырган колхоз бакчасы түгел.* Ф.Яруллин

**Тырпылдап тору** Һаман тырпылдау; сөйләү моментында тырпылдау. *Сабан туена бер атна калды дигәндә, [ат] баскан урынында тырпылдап кына тора башлады.* М.Гали. *Сәхия моның шулай икәнлеген аңлый, ләкин машина күрүгә утырырга тырпылдап торган малайны нәүмиз итәсе килми, тагын күтәреп ала.* Ф.Яруллин

**Тырпылдый башлау** Тырпылдарга керешү. *Һәм шуның бик зур файдасы булды: Рухия тавышын ишеткәч, читлегеннән чыгардай булып тырпылдый башлаган йөрәге шактый тынычланып калды, фикерләре яктырып китте.* В.Нуруллин

**ТЫРПЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **тырпылдау**. *Вагонның төрле почмакларында дуңгыз балалары чинаша, капчыкларда тырпылдашып яталар.* Ш.Галиев. *Обоз атлары тырпылдаша, машина кисәкләре, арба ватыклары кайсы кая тәгәрәшеп ята, нәрсәләрдер дөрләп яна.* Л.Гыймадиева

**ТЫРПЫЛДЫК** *с.* Тынычсыз, чәүчәләк, түземсез, көтәргә яратмый торган. *Тырпылдык кеше*

**ТЫ́Р-ПЫР** *иярт.* **1.** Берәр механизм, җайланма бик тиз хәрәкәт иткәндә, әйләнгәндә чыккан тавышны белдерә. *Күршеңнең мотоциклы бер дә туктап тормый ахры, көн буе тыр-пыр.* И.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шундый тавыш чыгарып. *Мотоциклга атланган чая кыз, тиз килер дип өмет итеп, моторын тыр-пыр эшләтеп, түземсезләнеп калган иде.* Ш.Галиев. *Тынычлык юк инде анысы, машиналар, мотоцикллар тыр-пыр чабыша.* Сөембикә

2) *сөйл. шелт.* Кеше сүзен кире кагып, кычкырынып. *– Тыр-пыр торып әниеңнең эчен пошырма, бар, урамга чык! – дип кычкырды бабасы малайга.* Кызыл таң

**3.** *хәб. функ.* Кычкырышу, кеше сүзен кире кагу. *[Фәгыйлә] Садыйк агайның үзгәнә үтә: «Колхоз дисең дә тыррр-пыррр, совет дисең дә черрр-меррр...»* Г.Толымбай

**ТЫ́Р-ПЫР ИТҮ** *ф.* 1) Әйләнгәндә, зур тизлек белән хәрәкәт иткәндә, һаваны ярып, коры, яңгыравык тавыш чыгару. *Тыр-пыр иткән матаеннан күзен ала алмады егет.* М.Мәһдиев

2) Кешегә кире сүз әйтү, киреләнү, үҗәтләнү. *Егетлек... Анысын тыр-пыр итеп кенә күрсәтеп йөреп булмый.* А.Гыйләҗев

**ТЫ́Р-ПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **тыр-пыр итү**. *Капка төбендә Саимә белән саубуллашты да, тыр-пыр килеп, урман*

*юлына чыгып чапты.* М.Мәһдиев. *Кешеләр янәшәңнән «Волга»да җилдереп үткәндә, тыр-пыр килеп, тузан эчендә мотоциклда чап-чап та, аннары үзеңне хөрмәт итүләрен, синең белән хисаплашуларын көт.* Р.Вәлиев

◊ **Тыр-пыр китерү** Кешеләрне төрле якка бик тиз тарату, йөгертү. *Дамба башында безне полиция тыр-пыр китереп куа башлады.* М.Максуд

**ТЫРПЫЧА** *и. диал. к.* **торыпша**. *Тырпычага солы салу*

**ТЫРР** *ы. к.* **трр**. *Афзал атларына йомшак-акрын гына: – Тырр, – диде.* М.Хуҗин. *Нәкъ әле генә тасвирлап язганча, чанадан төшеп калдык, атыбыз «тырр» дигәнне дә белми юыртты гына.* Т.Нәҗмиев

**ТЫ́РР ИТҮ** *ф.* Төрле транспорт чаралары зур тизлек белән барганда, коры, яңгыравык тавыш чыгару. *«Ни хәл, кара кашым?» – дип елмаеп кына эндәшсәм үзләренә: «Шәп әле, йолкышым», – диләр дә янымнан автомобиль кебек тырр итеп үтәләр дә китәләр.* А.Алиш

**ТЫ́РС-ТЫРС** *иярт.* 1) Каты басып йөргәндә яки сикергәндә чыккан тавышны белдерә; тасыр-тысыр. *Тырс-тырс, тырс-тырс... Абыйсының аяк тавышлары монда кадәр ишетелә.* Мәйдан

2) Йөгерү, тиз йөрү, бик кызу эшләү һ.б. аркасында йөрәкнең кызу-кызу тибү рәвешен белдерә

**ТЫРС-ТЫ́РС ИТҮ** *ф. к.* **тарсылдау**. *Йөрәк тырс-тырс итә*

**ТЫРСЫЛДА́У** *ф.* Нык-нык басып, авыр атлап йөрү, йөгерү. – *Тырсылдый әнә, тавышы монда кадәр ишетелә, – дип, яратмыйча әйтеп куйды Җәмиләсе.* Кызыл таң

**ТЫРТ** *иярт.* **1.** Атлаганда, йөгергәндә яисә нинди дә булса коралдан бер тапкыр атканда һ.б. чыккан тавышны белдерә. *Берзаман, «тырт! тыр-тыт!» итеп, пулемёт ата башлады.* Т.Нурмөхәммәтов. *Ату тавышы һавада эленеп калды: тырт...* Сабантуй

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, җәһәт. – *Һаман шул һавадагы торнага алданып йөрисең! – диде хатыны, төрттереп, һәм тырт кына өйгә кереп китте.* Х.Камалов

**ТЫРТАЮ** *ф. сөйл.* Ачулану, көйсезләнү, үпкәләү; турсаю. *«Вәт, картайган да тыртайган», – дип куйды Шаяз үзалдына.* Җ.Рәхимов. *Син, матурым, үгез сөзсә дә аумый торган багана төсле тыртаясың да катасың.* Н.Гыйматдинова

**ТЫ́РТ ИТҮ** *ф.* 1) Тиз генә, кинәт, җәһәт, көтмәгәндә, берни аңлатып тормыйча чыгу, китү, берәр хәрәкәт ясау. *Чөнки тегеләре тырт итеп борылалар да, шәһәргә китеп, шундый ук тракторга утыралар.* Г.Рәхим. *Ләкин ачуы чыккан кыз букетны чүп савытына томырды да, тырт итеп, тулай торакка йөгереп кереп китте.* З.Мәхмүди

2) Үпкәләү, турсаю. *Хәзерге кайбер яшь киленнәр төсле, тавыш чыккан саен, тырт итеп, әтиләренә йөгермәгән.* Ә.Еники

◊ **Тырт иткән саен** Кечкенә генә сәбәптән дә; берәр нәрсә ошамаса яки җае чыккан саен. *Болар хакына авыр корбаннар булачак, мәгәр бу аяусыз хөкем тырт иткән саен качарга әзер торган солдат массаларын уйландырыр, революцион кагыйдәнең һәркем өчен бер икәнен күрсәтер!* А.Гыйләҗев. *Тырт иткән саен: «Мин марҗа түгел – татар», – дияргә яратасың бит.* Ф.Баттал

**ТЫ́РТ-МЫРТ** *рәв.* **1.** 1) Еш-еш, вак адымнар ясап (атлау, йөгерү тур.). *Тырт-мырт йөгерешкән кызларга карап елмаеп куйды ул.* Кызыл таң

2) Юктан гына ачуланып, үпкәләп китеп, башкалар белән юньләп сөйләшмичә, ачык җаваплар бирмичә, киреләнеп. *Оныкка бу ошамый, тырт-мырт сөйләшә.* Ш.Галиев. *Авылга кайтып хур булгач, бигрәк тә әнисенең, өстән төшерелгән күрсәтмәне үтәп, тырт-пырт сөйләшүеннән кәефе кырылган иде.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Юкка ачуланучан, үпкәчән. *Тырт-мырт кеше*

**ТЫРТ-МЫ́РТ ИТҮ** *ф.* 1) Тегеләйгә-болайга атлау, йөгерү, әрле-бирле килү. *Тырт-мырт итеп йөрү*

2) Бик тиз ачулану, үпкәләү, башка кешеләр белән юньләп сөйләшмәү, ачык җаваплар бирмәү; киреләнү. *Каты холыклы ир, тырт-мырт итеп, сызган шырпыдай тиз кабынып китә торган хатын белән килешеп тора алмый.* С.Поварисов

**ТЫРТ-МЫ́РТ КИЛҮ** *ф. к.* **тырт-мырт итү**. *Алар шулай тырт-мырт килеп озак утырган булырлар иде, Миләүшә үзләренә таба килүче авыл егетләрен күреп алды.* Ф.Яруллин. *Аларында хатыны Хөршидә һәм дә шулай ук бер ботакта утыра алмаган чыпчык шикелле тырт-мырт килеп йөри торган кызы белән Әкмәли абзый көн итә.* Ф.Баттал

**ТЫРТ-ПЫРТ** *рәв.* **1.** *к.* **тырт-мырт 1.** *Үз чибәрлегенә үзе шаккатып йөрүче көязбикә дәшмәде, иренен пилмәндәй бөреп, ялкау карашы белән уң яктагы ишеккә ымлады да, тырт-пырт басып, юлын дәвам итте.* Р.Габделхакова

**2.** *с. мәгъ.* **тырт-мырт 2.** *Килендәшнең характеры тырт-пыртрак аның, малайга бер-бер хәл ясый күрмәсен.* В.Нуруллин

**ТЫРТ-ПЫ́РТ ИТҮ** *ф. к.* **тырт-мырт итү**. *Хатын, аңа башын борып карауга, аның ни исәп белән аларга сугылганлыгын чамалады һәм, тырт-пырт итеп, теге якка чыгып китте.* Х.Камалов

**ТЫРТ-ПЫ́РТ КИЛҮ** *ф.* 1) Кисәк-кисәк тырылдаган тавышлар чыгару, тыр-пыр килү. *Ләкин әз генә тырт-пырт килде дә көтмәгәндә ул да сүнеп китте.* Н.Фәттах

2) *к.* **тырт-мырт итү**. *Тырт-пырт килеп йөри инде ул шулай соңгы араларда ---.* Р.Вәлиева

**ТЫРТ-ПЫРТЛАНУ** *ф. к.* **тырт-мырт итү**. *Башка командирлар кебек тырт-пыртланмыйча, егет белән ипләп, малае белән фикерләшкән кебек сөйләште күрше батальон хуҗасы.* Т.Галиуллин

**ТЫ́РТ-ТЫРТ** *иярт.* **1.** Өзек-өзек, кыска-кыска шартлаулы яңгыравык тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кискен, кыска хәрәкәтләр ясап атлау, сикерү, ату һ.б. рәвеше; өзек-өзек хәрәкәтләнеп. *Аннары ул безнең янда бик озак әйләнгәләп йөрде дә минем кулга бер язу тоттырды, ә үзе тырт-тырт сикерде дә күрше бүлмәгә кереп китте.* А.Алиш

2) Еш-еш, вак-вак адымнар ясап; терк-терк. *Аннан күрмәкче бүтән тавыклар да чыркылдаша башлады, шул арада эре кыяфәт белән тырт-тырт басып, озын каурыйлары як-якка таралып торган койрыгын селкетеп, кызыл кикрикле купшы әтәч килеп чыкты.* Н.Фәттах. *Дөрес, Мөнирҗан атлар карарга иртәрәк кузгала, аны озатып күп тә үтми, хисапчы да колхоз идарәсенә тырт-тырт атлап китеп бара.* Н.Әхмәдиев

**ТЫ́РТ-ТЫРТ ИТҮ** *ф.* 1) Өзек-өзек шартлаулы яңгыравык тавыш чыгару. *Шул вакыт өйдән ниндидер кыштырдау, тырт-тырт иткән тавышлар килә башлады.* Шәһри Казан

2) Автоматтан, пулемёттан кыска-кыска, еш-еш ату. *Ул [пулемёт] өзек-өзек тырт-тырт итеп куйды, һавада утлы сызыклар сызды: зәңгәр җирлеккә кызыл җеп белән чигү чиккән сыман итте.* Х.Камалов

3) Еш-еш, вак-вак атлау, йөгерү. *Тырт-тырт итеп йөгереп йөрергә генә булсын инде аңа.* Р.Вәлиев

**ТЫРТЫК** *с.* 1) Бик кыскарган, бик кыска, курач (әйбер тур.). *Артык кылам дип тыртык кылма.* Мәкаль. *Тыртык чалбар*

2) Тиз үпкәли торган, көйсез. *Тыртык кеше*

**ТЫ́Р-ТЫР** *иярт.* **1.** Бер-бер артлы атканда, берәр нәрсә бик тиз әйләнгәндә яки ышкылып, бәрелеп барганда чыккан тавышны белдерә. *Мотор тавышы бөтен урамны яңгыратты: тыр-тыр, тыр-тыр.* Кызыл таң

**2.** *рәв. мәгъ.* Вак-вак адымнар белән тиз-тиз йөгерү, йөрү рәвешен белдерә. *Мәрьямбикә карчык баш өянәген онытты, көндезләрен мендәргә баш куеп хәл җыеп тормый, тыр-тыр чаба.* А.Гыйләҗев. *Авылның бер очыннан икенче очына тыр-тыр чапты.* Ф.Яруллин

**3.** *хәб. функ.* Кая да булса бик тиз һәм вак-вак атлап китүне белдерә. *Пальто якасын күтәрдем дә, түенчекне аркага асып, тыр-тыр...* Э.Касыймов

**ТЫ́Р-ТЫР ИТҮ** *ф.* 1) Мотор эшләгәндә, берәр нәрсә бик кызу әйләнгәндә яки ышкылганда тоташ булмаган ритмлы тавыш чыгару. *Кайдандыр тыр-тыр иткән эчпошыргыч тавыш ишетелә.* Р.Габделхакова

2) Вак-вак адымнар белән еш-еш атлап чабу, йөгерү

**ТЫ́Р-ТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **тыр-тыр итү**. *Тыр-тыр килеп йөгерешкән малларны күреп куркып китте.* И.Нуруллин. *Теге япун малаеның да, кем әйтмешли, башы почмакта, койрыгы учакта, ике бүрәнә арасына ауган да, тыр-тыр килеп җәфалана.* Ф.Баттал

**ТЫРЫ́ЙК-ТЫРЫЙК** *рәв. к.* **тырык-тырык**. *Бер якта аю малае шикелле итеп киендерелгән малай аватүнә атлый, икенче якта чак кына бөкрәя төшкән профессор картыбыз яны белән тырыйк-тырыйк баса, ә урталарында ике кулга эленгән шәп күнле портфель селкенә иде...* Э.Касыймов

**ТЫРЫ́К-ТЫРЫК** *рәв.* 1) Вак адымнар белән кызу гына атлап (бару, йөгерү тур.). *Артыннан теге сантый иярченнәре дә тырык-тырык теркелдәделәр.* Ф.Яхин. *Бераз тырык-тырык чабып баргач, ак кыр өстендә кинәт эреп югалуы сәерме?* Г.Гыйльманов

2) Арба белән каты, тигезсез, чокырлы-чакырлы юлдан селкенеп, дыңгырдап яки зур тизлектә барганда, бер ритмга чайкала-чайкала (бару). *Өлкәнәя барганда, Казан белән Әстерхан арасындагы дала буйлап, тырык-тырык, тәүлек буе йокы күрми, кеше көен көйләп йөрер идемени ул?* Н.Гариф. *Тырык-тырык тыркылдап барган поезд тәгәрмәчләренең тавышына уралып, шундый уйлар буталды Виленның башында.* М.Маликова

**ТЫРЫЛДАВЫК** *с.* **1.** Тырылдый торган; һәрвакыт тырылдап тора торган. *Малайларның кайберләре куллары на сырлы кер бәләге тоткан да, шул сырларга таяк белән ышкып, тырылдавык тавыш чыгара.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Ритмлы тавыш чыгара торган бәрмә уен коралы; шакылдавык; *русчасы:* **трещотка**. *Тырылдавыклар тырылдый, һәм башка төр уен кораллары уйный башлый.* Р.Мостафин

**ТЫРЫЛДАТУ** *ф.* 1) Пулемёт, автомат кебек кораллардан өзлексез ату. *Танклар да пулемёттан тырылдатырга керешә.* М.Шабаев. *Танкистларның үз расписаниеләре буенча өйрәнүләр билгеләнгән икән: пулемёт тырылдаталар, бөтен тирә-юньне дер селкетеп (палатка тәрәзәләре зыңлап тора), туптан гөрселдәтәләр.* Р.Кәрами

2) Тырылдаган тавышлар чыгарып эшләтү, йөртү (механизмнар, машиналар тур.). *Урманда бүрәнә чыгарганда, яфрак әзерләгәндә, күпме яшь агачларны харап итеп, трактор тырылдатабыз.* Р.Төхфәтуллин. *Элек тә бәйләнеп җаныма тия торган иде, ике көннең берендә, кич җиттеме – тәрәзә буена килеп туктый да моторын тырылдатырга тотына ---.* Гөлшәһидә

3) *куч.* Берәр нәрсә эшләргә, әйтергә кыстау; җилтерәтү. *Удмурт карчыгы, әнкәсенең сүзен раслагандай, «кешегез исән» дип тырылдатып куып җибәргәч, чәче дә яртылаш агарды...* Н.Гыйматдинова. *Малай һаман абыйсын тырылдата, югалган уенчыгын табып бирергә куша.* Сабантуй

**Тырылдата башлау** Тырылдатырга керешү. *Калашников автоматыннан аталар диярсең, тырылдата башлады бит куе кызыл төсләге пиджак кигән яшь кенә бер ир заты.* Я.Шәфыйков. *– Яңа ел күчтәнәчләрең кая, өләш безгә дә! – дип тырылдата башладылар.* Н.Гыйматдинова

**Тырылдатып алу** Кыска вакыт аралыгында тырылдату; бераз гына тырылдату. *Кинәт өстәлдән нидер шалтырап идәнгә төште, бер немец түшәмгә автоматтан тырылдатып алды, икенчесе пистолет белән идәнгә ата башлады.* Х.Камалов. *Хәлдән таеп егылса, автоматын тырылдатып ала.* Р.Мостафин

**Тырылдатып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә тырылдату. *Малай шулвакыт уенчык автоматын тырылдатып җибәрмәсенме...* Сабантуй

**Тырылдатып кую** Бер тапкыр тырылдату. *Автоматын кулга алып Куя бер тырылдатып, Тавыкларны, чебешләрне Куа ул пырылдатып!* Ш.Галиев

**ТЫРЫЛДА́У** *ф.* 1) Тыр-тыр иткән тавыш чыгару. *Алексей аның артыннан иярде, шулчак кайдадыр мотор тавышлары тырылдаганы ишетелде.* Х.Камалов. *Чәчүлек җирен карарга*

*агроном Хөснуллин бар, шуннан, чөгендер синсез дә үсәр, бу «Беларусь» синсез дә тырылдар.* Р.Камал

2) Шундый тавыш чыгарып ату. *Аларга станоклы пулемётларның тыкылдаулары, автомат тырылдаулары килеп кушыла.* Г.Әпсәләмов. *Шул ук мизгелдә ишек төбендә немец автоматы озын чират биреп тырылдарга тотынды.* З.Зәйнуллин

3) *күч.* Бертуктаусыз сөйләү. *Мескен [малай], икенче койка астына кереп бара, туктаусыз тырылдаган була үзе.* С.Шәрипов. *Бәдәр тырылдаган сүзләрне ишетте дә ул, ишетмәде дә.* В.Имамов

4) *күч.* Бертуктаусыз йөгерү. *Көне буе тегендә-монда тырылдап йөреп тә эш барамы шулай?* Кызыл таң

**Тырылдап алу** Аз гына тырылдау, кыска вакыт аралыгында тырылдау. *Аннары уң флангтанрак икенче пулемёт тырылдап алды.* Х.Камалов. *Авыл читендә автомат тырылдап алды.* М.Мәһдиев

**Тырылдап кую** Бер тапкыр, аз гына тырылдау. *Сулда һәм уңда, шактый еракта, һавага ракеталар чөяләр, ара-тирә автоматлар тырылдап куя.* Г.Әпсәләмов. *Шырпы яктысы күренү белән, капка янындагы пулемёт тырылдап куя.* Н.Дәүләтшин

**Тырылдап тору** Озак вакыт дәвамында тырылдау, даими тырылдау. *Бер-ике мәртәбә тук-тук итеп аермачык итеп агачка суга да, аннары тырррррр итеп тырылдап тора башлый.* Г.Ахунов. *Тырылдап тора мотор, Төтене зәңгәр, матур ---.* Р.Шәрипов

**Тырылдый башлау** Тырылдарга тотыну. *[Сәгать] Менә-менә тырылдый башлар дип, сагаеп ятам.* Ш.Галиев. *Пулемёт тырылдый башлагач ук дөядән җиргә сикергән, тын алырга да куркып, борыннарын комга төртеп яткан ике кәрванчы әсир ителде.* Т.Әйди

**Тырылдый бирү** Һаман тырылдау; бернигә дә карамый тырылдау. *Пулемётлар һаман тырылдый бирә*

**ТЫРЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **тырылдау**. *Аның артыннан дәү кырмыскаларны хәтерләткән «Беларусь» тракторлары бер-бер артлы тырылдашып килеп чыкты.* Г.Ахунов

**Тырылдаша башлау** Тырылдашырга тотыну. *Яз җиткәч, тракторлар тырылдаша башлый.* Ш.Маннур

**Тырылдашып алу** Кыска вакыт эчендә тырылдашу. *Автоматлар тырылдашып алды.* Г.Әпсәләмов

**ТЫРЫЛДЫК** *с.* **1.** Бик нык тырылдый (*1 мәгъ.*) торган. *Әллә сабый чакта ук: «Таптап, сытып үтә күрмәсен тагын тырылдык нәмәрсә», – дип шүрләү белән үкчә ялтыраткандамы?* Р.Төхфәтуллин. *Өстән таптатып киткәндәй колак тондыргыч тырылдык тавыш белән берьюлы әллә ничә мотоцикл узды.* Х.Низамов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тырылдый торган нәрсә (мәс., мотоцикл). --- *шушы тырылдыкны йөртер өчен дә укырга кирәк.* В.Нуруллин. *Төшкәндә инде, билгеле ки, ул тырылдыкның исеме нибары «матай» иде.* З.Мифтахов

2) Бертуктамый сөйләүче кеше. *Ул тырылдыкны туктатып булмый, сөйли дә сөйли*

**ТЫРЫМ-ТЫРАГАЙ** *рәв. сөйл.* **1.** Тәртипсез рәвештә теләсә кая таралып, чәчелеп. *Мин борчылмасам, бу район әллә кайчан тырым-тырагай булып бетәр иде.* З.Мурсиев. *Дөнья капыл караңгыланып китте: әллә аң-зиһенгә чак барып җиткән кара кайгыдан, әллә тырым-тырагай таралышып яткан кара кисәүләрдән [күзе томаланды]?..* Г.Якупова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тәртипсез, җыйнаксыз. *Тырым-тырагай бу йортка килеп керүгә үк хәлне аңлап алды ул.* Р.Вәлиев

2) *күч.* Җәмгыятьтә әһәмиятле урын тотмаган, җитди булмаган (кешеләр тур.); этрәк-әләм. *Гел тырым-тырагай кешеләрне генә җыеп тутырганнар диярсең ---.* Ш.Маннур

**ТЫРЫС** *и.* 1) Чиләк сыман итеп туздан ясалган савыт. *Әйтик, «каен тузыннан эшләнгән һәм капкач белән ябыла торган тырыста су хәтта көчле салкында да туңмый».* Ш.Галиев. *Ә инде тапсаң, гөмбәнең дымсу такыр башына кунган яфрак кисәкләрен әкрен генә сыпырып төшерәсең, ләкин кисеп тырыска салырга ашыкмыйсың.* Н.Гыйматдинова

2) Шундый савытка сыешлы әйбернең микъдар күләме. *Күз ачып йомганчы җиләк җыйдык бер тырыс.* Сөембикә

**ТЫРЫСЛЫК** *с.* **1.** Тырыс ясар өчен яраклы. *Тырыслык туз*

**2.** *и. мәгъ.* Тырыс ясар өчен яраклы туз, кабык. *Кайры белән агач кәүсәсе арасына шул озын агач пычакны тыгып шөшкели торгач, тырыслыгыбыз агачыннан кубып суырылып чыкты.* Ш.Маннур

**ТЫРЫШ** *с.* **1.** 1) Күңел биреп, бөтен көчен һәм сәләтен җигеп эшли торган. *Кытайлар – тырыш, үҗәт халык.* Р.Батулла. *Гатаулла кебек тырыш кешене әүвәле эзләп табыгыз, аннан соң телегезгә алып әйтерсез.* Ф.Яхин

2) Ихлас күңелдән, бар көчне куеп башкарылган. *Тырыш хезмәт нәтиҗәсендә табылган мал, хуҗалык тартып алына.* Х.Садри. *Тырыш эшең сиңа дан бирер, Борчыласың нигә бер дә юкка, Тормыш кыен түгел, яши бел!* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Тырышның тире чыкканчы, ялкауның җаны чыгар.* Мәкаль. *Тырышның эше күп, ялкауның эше юк.* Ш.Галиев. *Тырышның кадерен дә белеп бетермиләр.* Ф.Яхин

**ТЫРЫША́-ТЫРМАША** *рәв.* Зур тырышлык, көч куеп; кыенлыкларны җиңеп. *Тырыша-тырмаша торгач, башта «Тамчыгөл»не, аннан Тукайның «Туган тел» көен шома гына уйный башлады Гали.* Г.Галиев. *Кайберәүләр тырыша-тырмаша акча җыя, гадел юл белән дә, дәүләт кесәсенә керә-керә дә баерга тырыша.* Р.Миңнуллин

**ТЫРЫШЛЫК** *и.* 1) Тырыш булу сыйфаты. *Моның өчен иң әүвәл табигый талант һәм тырышлык кирәк.* Н.Фәттах. *Ләкин бит алай язар өчен дә, никадәр зур сәләт, тырышлык һәм түземлек кирәк.* В.Нуруллин

2) Максатка, теләккә ирешү өчен киткән эшчәнлек, көч, энергия. *Мин аның дәресләренә аерата тырышлык белән әзерләнеп барам.* А.Гыйләҗев. *Бәлки, шуңадыр, институтны бик яхшы тәмамладым, мине кафедрада калдырдылар, бик тиз кандидатлык*

*диссертациясен якладым һәм зур тырышлык белән докторлык диссертациясе язарга керештем.* М.Маликова

**ТЫРЫШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тырышу**. *Күп тырыштырды, күп төрле юллар белән мине кызыктырып бакты, үпкәләде, ачуланды, ләкин артык зур нәтиҗә чыга алмады.* Г.Ибраһимов. *Бу кызны да шул хис тырыштырамы?* Х.Камалов

2) Берәр эшне булдыра алган кадәр башкару; юнәтү, булдыру. *Үзара татулыгың, баш куярга бер мендәрең булса, калганын тора-бара тырыштырасың аны.* Г.Бәширов. *– Минә дәү абыегыз сезнең өчен тырыштырды инде, – диде карчык, күзе белән генә Зөфәргә ишарәләп.* Ә.Еники

**Тырыштыра бирү** Бернигә карамый тырыштыру. *Математикага көч салсам, әзрәк географияне тырыштыра бирсәм, башка фәннәр белән минем ара болай да ал да гөл!* Т.Гарипова

**Тырыштырып карау** Сынау, тикшерү максаты белән тырыштыру. *Болай тырыштырып карадым каравын да.* Һ.Такташ. *Аны гына тырыштырып карарга мөмкиндер ул!* А.Хәлим

**Тырыштырып килү** Озак вакыт дәвамында тырыштыру, гел тырыштыру. *Сәрвиянең малае бер Тимерша тырыштырып килә.* М.Хуҗин

**ТЫРЫШУ** *ф.* 1) Нинди дә булса эшне ихлас күңел белән көч куеп башкару, үтәү. *Йорт өчен тырышуын күреп, һич аңарга каты бәрелми, фәкать мыегын сыйпаштырып, Алла ярдәм бирсен үзләренә, дип, әңгәмәгә нокта куймакчы була.* К.Миңлебаев. *Әгәр дә андый характерны уртага куеп әсәр язарга җыенсаң, әллә ни тырышасы да юктыр.* Т.Миңнуллин

2) Үзеннән алда килгән фигыль белән белдерелгән максатка, теләккә ирешү өчен көч кую. *Биктимер беренче егеткә күз кыса, чыгарга күрсәтеп башын чайкый, читкәрәк китәргә дигән мәгънәне аңлатырга тырыша.* А.Алиш. *Университет бетерәләр дә, кайберләре хәтта аннан-моннан юллап Казанда калырга тырышалар.* А.Хәсәнов

**Тырыша башлау** Тырышырга тотыну. *Кемдер арттан Тотышның яңадан кулларын тотып алды, кемдер бау белән бәйләргә тырыша башлады.* Н.Фәттах. *Юк, авырткан җиреңә кагылсалар, җаныңа якыннарың, гаиләң, балаң аша үтеп керергә тырыша башласалар, салкын канлы булып калу авыр икән.* З.Зәйнуллин

**Тырыша бирү** Бернигә дә карамый тырышу. *– Булат, синме? Әйдә! – диде дә, төнге мөсафирларны, ишек-бусагаларга лампа яктысын төшерергә тырыша биреп, эчкә алып керде.* Г.Ибраһимов. *Иртәдән кичкә хәтле үз уй-ниятләремне үтим дип чаба, җанфәрман тырыша бирдем.* М.Вәлиев

**Тырыша төшү** Элеккегә караганда да күбрәк тырышу, тагын да ныграк тырышу. *– Эшләрегез нигездә әйбәт, әмма тагын да тырыша төшегез, – диде секретарь.* С.Шакир. *Мондый хыял йөрткәч, тагын да тырыша төшәсең.* Сабантуй

**Тырышып карау** Максатка, теләккә ирешү өчен омтылыш ясау. *Аны комган белән тышка да йөртте, иман кәлимәләрен дә ятлатырга тырышып карады, ләкин ни файда?* А.Алиш. *Фрау берничә тапкыр Азат белән җитди сөйләшергә тырышып карый каравын, ләкин аның үзенең дә тормышка үзгәрешләр кертәсе килми шикелле.* А.Тимергалин

**ТЫРЫШУЧАН** *с.* 1) *к.* **тырыш**. *Г.Бубиның артык тырышучан, «яхшы администратор һәм киң фикерле җәмәгать хадиме» икәнлеге монда да раслана.* М.Мәһдиев

2) Берәр эшне башкарырга омтылучан. *Безнең әни, әти фронтта вакытта күргән авырлыклардан саулыгын җуеп, төрле сырхаудан йөдәгән кеше булгангамы, көчсез-зәгыйфьләрне, авыруларны җәлләүчән, аларга ничек тә ярдәм итәргә тырышучан иде.* Ш.Маннапов. *Кешеләрне аңларга, аларның теләкләрен, гозерләрен кабул итәргә тырышучан [Солтан].* Ф.Яхин

**ТЫРЫШУЧАНЛЫК** *и.* Тырышучан булу сыйфаты. *Җәләшнең эгоист табигате, һәр җирдә үзен күрсәтергә тырышучанлыгы аның сөйләү тонында, ике сүзнең берендә очраган «мин»нәрендә үк чагыла.* М.Хәсәнов

**ТЫРЫШЧАН** *с. ялг. к.* **тырыш, тырышучан**. *Без – бик эшчән, тырышчан бер халык.* Г.Тукай. *Бу авыллардан, икесеннән дә, яшьләр китми, авыл кешеләре үзләренә кәсеп тапканнар: Мәскәүгә ит, казы ташыйлар, төзү эшләрен дә үзләре үк башкара, аракы белән бик мавыкмыйлар, тырышчан, эш сөючән халык.* М.Миначев

**ТЫРЫШЧАНЛЫК** *и. ялг. к.* **тырышлык**. Тырышчан булу сыйфаты. *Күп кешеләргә уңышлы булу өчен түземлелек, тырышчанлык, ихтыяр көче җитми дә инде.* Ф.Баттал. *Девишев постановкаларындагы яңалык, тырышчанлык, эзләнүчәнлек һәм осталыклар булганлыгын тагын бер кат кабатлыйбыз.* Гасырлар авазы

**ТЫРЫШЫ́П-ТЫРМАШЫП** *рәв. к.* **тырыша-тырмаша**. *Тырышып-тырмашып, чын күңелдән язган эчкерсез хатыңны алдым.* Ф.Яруллин. *Әмин менә, тырышып-тырмашып та көчкә-көчкә сигез сыйныфны тәмамлап, тугызга кергән идем.* З.Зәйнуллин

**ТЫСЫЛДА́У** *ф.* Тсс итү. *Тысылдама, аңладым инде болай да.* Сабантуй

**Тысылдап кую** Бер тапкыр тысылдау. *Кыз тысылдап куйды, шауламагыз, янәсе.* Р.Вәлиева

**Тысылдап тору** Озак вакыт дәвамында тысылдау. *– Тысылдап торма әле, – дисә дә, сеңелкәшенә карап елмаймыйча түзмәде ул.* Кызыл таң

**ТЫСЫ́Р-ТАСЫР** *иярт. к.* **тасыр-тасыр**. *Тысыр-тасыр чабышып, Менә кызык табалар [балалар].* Н.Думави. *Тысыр-тасыр йөгергән малайларга карап, үзенең кечкенә чакларын искә төшерде ул.* М.Вәлиев

**ТЫТ-ТЫТ** *иярт. к.* **пыт-пыт**. *– Бу машина тыт-тыт иткән тавышлар чыгара, – дип, әтисе кайтуга, Алмаз сөенече белән бүлешергә керешә.* Сабантуй

**ТЫТЫЛДА́У** *ф. сөйл. к.* **тәтелдәү**. *Юл буе тытылдап барган апасына ачуы да килгәндер инде малайның.* Ш.Маннур. *Мин бик кечкенәдән үк Тукайга, Пушкинга ияреп русча, татарча тытылдап, сакау телем белән шигырь әйтә башлаганмын.* Кәеф ничек?

**Тытылдап йөрү** Озак вакыт дәвамында тытылдау. *Барыбыз да аңлыйбыз инде: тытылдап йөргән абый ачуын чыгара аның.* Р.Рахман

**Тытылдап тору** Сөйләү моментында тытылдау; гел, әледән-әле тытылдау. – *Ул тытылдап торсын, ә син үз эшеңне бел, – диде апа.* Кызыл таң

**Тытылдый бирү** Һаман тытылдау; бернигә карамый тытылдау. *Әби беркемне тыңламый, үзенекен тытылдый бирә.* Сөембикә

**ТЫТЫП** *кис. диал.* Бөтенләй, нәкъ, тач. *Кызыбызны адәм арасында кимхур итмәбез. Тытып атасы бит ул, күрекле.* Э.Касыймов

**ТЫЧКАК** *с.* Зур хаҗәтен еш үти торган. *Бер тычкак мәчеләре бар иде.* Р.Батулла. *Моның өстенә берәр тычкак сыер килеп басса да ишелеп төшә бит бу.* Ф.Сафиуллин

**ТЫЧКАН** *и.* 1) Тычкансыманнар семьялыгыннан хуҗалыкка зыян китерә торган, озынча башлы, озын шәрә койрыклы, гадәттә соры төстәге вак кимерүче хайван. *Тычкан, тәмле ипи валчыгы исен шунда ук сизеп, тиз генә аның учына менеп утыра, ипи валчыкларын борынын, мыекларын матур кыймылдатып ашап та җибәрә.* Н.Каштанов. *Мәчеләр, тычкан аулыйсы урынга, өстәлгә менеп, кешенең үзе өчен әзерләгән ризыгын ашый.* Р.Габделхакова

2) Гадәттә атның корсагында, янтыгында була торган һәм бик каты чәнчүдән гыйбарәт авыру. – *Атта тычкан чире, тычкан, тычкан, – диде Нургата.* А.Расих

3) *махс.* Атларда була торган, борын һәм бугаздагы лайлалы катлау ялкынсынуыннан гыйбарәт йогышлы авыру; *русчасы:* **мыт**. *[Афзал:] Хәзер миңа, атны җитәкләп, сукыр Әкәми килгән иде. Мескеннең атына тычкан булган.* Т.Гыйззәт

4) *информ.* Компьютерга төрле командалар бирү һәм курсор белән идарә итү җайланмасы. *Башка спорт уеннарыннан аермалы буларак, әлеге чемпионатта катнашучыларга банк карталарын кәрзингә ыргытып та, компьютер тычканы белән йөгерү осталыгын да күрсәтергә туры килде.* Мәйдан

5) *күч.* Ике башлы мускулның (бицепсның) кинәт сукканда кабарган өлеше. *Алар, ялан аяклары белән таптанып, беләк тычканнарын нык кабартып, әледән-әле бер берсенә очынып кунып алдылар.* Н.Фәттах

◊ **Тычкан азыгы** Ашалмыйча әрәм булып яткан ашамлык. **Тычкан аулаган мәче кебек (сыман)** Сиздермичә, сак кына. *Тычкан аулаган мәче кебегрәк кылана шул Карпович.* С.Шәрипов. **Тычкан аулаган песи кебек (сыман)** *к.* **тычкан аулаган мәче кебек**. *Шуңа күрә тычкан аулаган песи кебек посып кына күзәтеп ята да, җай чыгу белән дәррәү сикереп, буып ташламакчы була.* С.Поварисов. *Тычкан аулаган песи сыман күзәтеп торыр инде һаман.* Р.Вәлиева. **Тычкан ашарлык та** Бик аз гына да, бөтенләй булмау турында. *Безнең [келәттә] тычкан ашарлык та азыгыбыз юк.* Т.Гыйззәт. *Тик күп очракларда крестьянны амбарында тычкан ашарлык та ашлыгы калмаган колхозга бәйләп тоталар!* Кызыл таң. **Тычкан баласы узарлык** *к.* **тычкан узарлык**. *Балкон каршында торган бал мичкәсенең агач капкачы күтәрелде. Чак кына, тычкан баласы узарлык кына.* Х.Ибраһим. **Тычкан башын ярырлык** Нәрсәнең дә булса буш, иркен булуы турында. *Халык таралганда, Баһауның ларёгында тычкан башын ярырлык бушлык була.* М.Мәһдиев. *Суыткычыгыз тычкан башын ярырлык, башкасы турында әйтмим дә инде, кефир белән сөт кенә дә юк.* Р.Вәлиев. **Тычкан башы ярылыр** *к.* **тычкан башын ярырлык.** *Ә хәзер берсе дә мөмкин түгел: сукмаган көлтәне сатып булмый; келәткә керсәң, өсәкләрдә тычкан башы ярылыр.* Г.Ибраһимов. **Тычкан башы ярылырлык** *к.* **тычкан башын ярырлык**. *Бура төпләре тап-такыр, тычкан башы ярылырлык.* Г.Бәширов. **Тычкан бәбәк** *хурл.* Бик кечкенә һәм бик хәрәкәтчән, елтыр күзле кеше турында. *«Тычкан бәбәк» дип Фатихәттәй Яңгураны әйтә иде.* Г.Әпсәләмов. **Тычкан борыны үтмәс** Бик еш, бик куе. *Тычкан борыны үтмәс чытырманлыкны ничек чыгарсың, балам?* Әкият. **Тычканга ташланган песи кебек** Бик тиз, җәһәт, озак уйлап тормыйча. *Акылыннан шашкан ана чырылдап кычкырып җибәрде, тычканга ташланган песи кебек, бар көченә камыл арасына ыргылды.* Н.Фәттах. **Тычкан да үтеп йөри алырлык** *к.* **тычкан борыны үтмәс**. *Шуңа күрә камалыштан кеше түгел, тычкан да үтеп йөри алырлык булмасын!* Р.Сәгъди. **Тычкан йөрәкле** Куркак. *Әлбәттә инде, мондый кыз тычкан йөрәкле, камыр беләкле Фоатка тиң түгел иде.* Ф.Яруллин. **Тычкан кимерерлек** *к.* **тычкан ашарлык та**. *Тычкан кимерерлек азыклары да калмаган кешеләрдән ни көтәргә?* Мәйдан. **Тычкан койрыгы кебек (төсле, сыман)** Бик юка, нәзек, гадәттә, нечкә чәч үреме турында. *Кайчандыр аркан очлары кебек салынып торган калын кара толымнары хәзер зур көмеш тәңкә тагылган тычкан койрыгы кебек кенә булып калган.* Р.Кәрами. *Ул тычкан койрыгы сыман бөтәрләнеп килгән тар кашлары астыннан сөзеп төбәлгәндә, аның бораулы, утлы карашы дәү-дәү ирләрне дә бер карышка чүктергәндәй итә.* В.Имамов. **Тычкан күз** 1) *хурл.* *к.* **тычкан бәбәк**. *Тор әйдә, тычкан күз!* Ә.Зарипов; 2) Кечкенә елтыр күзләр турында. *«Әйттем мин сиңа!» – дигән шикелле, тычкан күзләрен зәһәрле елтыратып, иренә бер карап алды да, ашыгып, эссе чәй чөмерергә тотынды.* Н.Фәттах. **Тычкан күзәткән мәчедәй** Бик нык игътибар белән, күзен дә алмыйча, күздән югалтмыйча; бернинди дә тавыш чыгармыйча, тыныч кына. *Тычкан күзәткән мәчедәй, Фоат артыннан гел күзәтеп кенә йөрде, ә инде Фоат класста берәр кыз белән генә калса, ишекне терәтеп куеп, боларны чыгармыйча интектерә иде.* Ф.Яруллин. **Тычкан күзе** *к.* **тычкан уты** (*4 мәгъ.*). *Беренче бүлмәдә тычкан күзе генә яна.* Г.Әпсәләмов. *Ә ыңгырашу тәмам якынайгач, алдан сөйләшенгән буенча, «тычкан күзен» – кытай фонарен – өч мәртәбә яндырып алдым.* Н.Гамбәр. **Тычкан күзе кадәр (кебек, хәтле, чаклы)** Бик кечкенә нәрсә яисә кечкенә булып ялтырап күренгән ут турында. *Ә тәрәзәдә, малайкай, тыч-*

*кан күзе кадәр генә ут яна.* Н.Фәттах. *Уртасына тычкан күзе хәтле генә май тамызалар.* А.Хәсәнов. *Мишеньдә, бер тиен акча зурлыгындагы унлы ак түгәрәкнең нәкъ уртасында, тычкан күзе кебек кенә кара тишек хасил булган иде.* Г.Рәхим. **Тычкан күзенә кырып салырлык** Бик аз. *Ярдәм, диләр, ләкин шунысы бик сәер: Тычкан күзенә кырып салырлык хәер!* Р.Ханнанов. **Тычкан күзенә сибәрлек (тә)** Бик аз гына да. *Җитмәсә, фатирга түләрлек акча, тычкан күзенә сибәрлек азык калмады.* Ш.Бикчурин. **Тычкан лампасы** *к.* **тычкан уты** (*4 мәгъ.*). *Мин синең шикелле, [китапны] төн буенча тычкан лампасы белән дә укып чыга идем.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Безнең әбибабайлар тычкан лампасы яктысында укыганнар.* Кызыл таң. **Тычканлы-мәчеле (уены) уйнау** 1) Күзләре бәйләнгән баланың башка балаларны эзләп, куып йөрүеннән гыйбарәт уен; 2) Шаярту, кызык өчен йөрү. *Берәр офицер белән танышып, тычканлы-мәчеле уены уйнасаң, үзеңә җиңелрәк булыр.* Х.Камалов. *Тычканлы-мәчеле уйнарга яраттылар, тыштан ялтырап та, эчләре хәйлә белән тулган --- егет кесәсе исәбеннән шоколад кимерергә һәм кинога чабарга ашкынып торучы тәмле тамак, шыр сыйрак булып чыктылар.* Ф.Хөсни. **Тычкан саклаган мәчедәй (мәче кебек)** *к.* **тычкан күзәткән мәчедәй**. *Тычкан саклаган мәче кебек, бик сакланып кына, бик акрын гына күкрәгем өстеннән шуып, шул йоклаган солдатка таба киттем.* Ш.Мөхәммәдев. *Тычкан саклаган мәчедәй, иртән дә, кичен дә подъезд төбендә уралырга тырышты.* Ф.Баттал. **Тычкан сыртлы** 1) Артык таләпчән; вакчыл. *Эзләнә торгач, председательнең тычкан сыртлыгына тап булдык, иптәшкәйләрем, вакытлы-вакытсыз йөткереп тә булмый хәзер.* Ф.Хөсни; 2) Сер, сәбәп. *Эрмитажга йөрүдән килеп чыккан тамашаның тычкан сыртлысы шунда: монда мин бер түтәй белән таныштым.* Ф.Хөсни. **Тычкан танавын да канатмаган** Бернинди батырлык кылмаган, үз көчен күрсәтмәгән. *Син бит тычканның танавын да канатмаган кеше.* М.Хәсәнов. **Тычкан таяк белән йөри торган (йөрер)** Бик сак булуны таләп итә торган (заман, вакыт тур.). *Заманалар бик болгавыр, тычкан таяк белән йөри торган вакыт, шул тикле байлыкны яман күзгә күрсәтү юньлегә илтмәячәк.* Г.Ахунов. *– Заман – кара төн, кешеләре – ерткычҗанвар, – диде карчык. – Тычкан таяк белән йөрер вакыт, сакланганны Алла саклаган.* Ә.Галиев. **Тычкан тәбесе** Засада; гомумән кыен хәл, котылгысыз капкын. *[Комбат:] Тычкан тәбесе! Кая ата алам, күрегез! – Әмма кече лейтенантның ризасызлыгы карышу түгел иде, шуңа комбатның ачуы килмәде.* Х.Камалов. **Тычкан тоткан песи кебек** *к.* **тычканга ташланган песи кебек**. *Тычкан тоткан песи кебек кенә эләктереп ала, дим.* Т.Гыйззәт. **Тычкан туярлык та** *к.* **тычкан ашарлык та**. *Кая ул мал! Тычкан туярлык та ашлыгың булмасын ларыңда.* Р.Вәлиева. **Тычкан узарлык түгел** *к.* **тычкан борыны үтмәс**. *Сигез кабинетның һәркайсында – икешәр педагог, коридорларда тагын җиде кеше күзәтчелек итә. Кыскасы, тычкан да узарлык түгел.* Н.Вахитов. **Тычкан урынына буып ташлау** Кемне дә булса бик җиңел үтерү, юк итү, кимсетү. *Алайга китсә, хәзер җимереп, басып кирерләр, тычкан урынына буып ташларлар, малайкай!* Н.Фәттах. **Тычкан урынына сыту** *к.* **тычкан урынына буып ташлау**. *Әхимне бераз читкәрәк этәрде дә калтыранган тавыш белән пышылдады: – Йөгер, егет, тиз бул! Югыйсә ул сине тычкан урынына сытачак.* Ф.Зыятдинов. **Тычкан үтмәслек** *к.* **тычкан борыны үтмәс**. *Төшкәч, патша улы әйтә: – Тычкан үтмәслек чыршылык.* Әкият

**ТЫЧКА́Н БОРЧАГЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан бөтерелмә сабаклы, куш чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; бормалы үлән; *русчасы:* **горошек мышиный**. *Орлыкны, хайваннарга ашатыр алдыннан, тар яфраклы тычкан борчагы орлыкларыннан чистартырга я булмаса югары температурада эшкәртергә (эссе суда яки парда пешерергә) кирәк.* Агулы үсемлекләр. *Тычкан борчагы күп чәчәкле вика дип тә атала.* Ботаника

**ТЫЧКА́Н ЕЛЫ** *и.* Төрки халыкларда һәр елы берәр хайван исеме белән аталган борынгы уникеellлык циклның беренче елы. *Гөлек баба тугыз йөз унынчы елда, тычкан елында туган.* Р.Батулла. *Тычкан елында тугачтын, Мин, мөгаен, тычкандыр.* Р.Миңнуллин

**ТЫЧКАНКОЙРЫК** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан басу читләрендә, юл буйларында үсә торган, озынча кыяк яфраклы, вак чәчәкле, чук тамырлы берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **мышехвостник**. *Кайткач апасына күрсәтер өчен, юл буенда үскән тычканкойрыкларны фотога төшерде, ромашка чәчәге җыйды.* Сөембикә

**ТЫЧКАН-КҮСЕ** *җый. и.* Вак кимерүче хайваннар. *--- Йоклый ул, төш күрә, Төшендә дә тычкан-күсе Халкы белән эш күрә.* К.Миңлебаев. *Бата торган корабльдән тычкан-күселәр качкан кебек, рәтле кешеләр моннан качып беткән ---.* Ф.Яруллин

**ТЫЧКА́Н САЛЫШ** *и. этн. к.* **йөзек салыш**. *Югыйсә аулак өйдә уеннар бик күп («Каеш ташлау», «Почталы», «Кем сукты», «Тычкан салыш», «Ярирлы», «Булавка яшереш», «Күгәрчен ашату» һәм башка уннарча уен.).* Н.Исәнбәт. *Мин дә шаккатам аңа! Качышлы уйнамыйлар, тычкан салыш бетте, күз бәйләш тә онытылды.* А.Гыйләҗев

**ТЫЧКА́Н САРЫМСАГЫ** *и. бот. диал.* Лаләчәләр семьялыгыннан суганга һәм сарымсакка хас барлык сыйфатларга ия булган һәм кыягы аштәмләткеч итеп файдаланыла торган күпьеллык тугай үсемлеге; юа. *русчасы:* **лук душистый**. *Безнең болыннарда тычкан сарымсагы үсә иде, юа да диләр әле аңа.* Сөембикә

**ТЫЧКА́НСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан авыл һәм урман хуҗалыгына зыян китерә торган имезүче хайваннарның якынча 480 төрен берләштергән семьялык. *Бөер синдромлы геморрагик бизгәк авыруын профилактикалауның барлык чаралары да кешенең тычкансыманнар,*

*аларның бүлендекләре белән элемтәгә керүне кисәтүне һәм азык-төлекне, суны аларның бүлендекләре белән пычранудан саклауны үз эченә ала.* Туган як

**ТЫЧКА́Н ТАРЫСЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан башакларында җирәнсу яки яшькелт кыллары булган берьеллык яки күпьеллык чүп үлән; *русчасы:* **щетинник зелёный**. *Ул урынны хәзер эт эчәге, тычкан тарысы басып киткән.* Р.Вәлиев. *Зарарлы үләннәрдән күгелҗем тычкан тарысы --- хайваннар өчен зыянлы булырга мөмкин.* Агулы үсемлекләр

**ТЫЧКА́Н УТЫ** *и. бот.* 1) *диал.* Утлы коңгыз. *Берәү урманда тычкан уты табып, учына куя да: – Тырнак хәтле генә мәхлук, кара син аны ничек яктырта! – ди.* Ш.Галиев. *– Минем тычкан уты бөҗәкләре бар, – дип, Дилбегә куеныннан пыяла савыт тартып чыгарды һәм җиңелчә генә савытны селкеткәләде.* Р.Нуруллин

2) Черек агачның төнлә күренә торган яктысы. *Менә караңгы төште, черек төпләрдә тычкан утлары кабынды.* Җ.Тәрҗеманов

3) Бик начар яна торган сукыр лампа. *Фургонның арткы ишеге ачылып, түшәмдәге тычкан уты урынына көзге кояшның күз камаштыргыч яктысы ургылып керә, һәм оперның: «Арестованный Сәйдәшевләр! Балалар белән саубуллашыгыз!» – дигән карлыккан тавышы ишетелә.* А.Тимергалин. *Ә хәзергә – рәшәткәле тәрәз, Лампа уты тычкан уты сыман.* Р.Низамиев

4) Бик аз гына яктырта һәм тонык кына күренә торган кечерәк ут. *Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен, – әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара.* Ә.Еники. *Тычкан уты хәтле яктылык юк, Табылырмы чыгу юллары?!* Ф.Зыятдинова

**ТЫЧКАНЧЫК** *и. к.* **тычкан** (*3, 4 мәгъ.*). *Тычканчык авыруы*

**ТЫЧКАН-ЯЛМАН** *җый. и. к.* **тычкан-күсе.** *Төлке булмаса, тычкан-ялманнар җир өстен каплар иде.* Г.Хөсәенов

**ТЫЧТ** *иярт.* Авыздан төкерекне бик кыска һәм нечкә итеп төкергәндә чыккан тавышны белдерә; чырт, лачт. *– Үзең эшлә алайса, кем дип белдегез соң мине? – дип кычкырды да ачуыннан төкерде... Тычт.* И.Нуруллин

**ТЫ́ЧТ ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару; шундый тавыш чыгарып төкерү. *Гата тәмәке төтененнән саргайган сап-сары эре тешләре арасыннан тычт итеп идәнгә төкерде, Солтанга таба яны беләнрәк борылып: – Нәрсә, мәхдүмәгә әллә үзеңнең күзен төштеме? – диде.* Г.Ахунов

**ТЫЧТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **тычу**. *Кечкенә балаларны сидерергә дә, тычтырырга да туры килә*

2) *куч.* Ашыктыру, хәзер үк сорау; нәрсәне дә булса тиз арада, ашыгыч эшләп бирүне, үтәүне һ.б. таләп итү. *Мөгаен, чукынып та җибәрергә туры киләчәк. Халык әйтмешли: «Тычмас идем, урыс тычтыра!»* Безнең гәҗит

**ТЫЧУ** *ф.* Олы хаҗәтне үтәү. *Ой-ой, кабахәт күгәрченнәр башыма тыча*! Н.Гыйматдинова. *Татар халкының бик каты әйтелгән мәкале бар: тычмаган күткә бук ябышмый, диләр.* Безнең гәҗит

◊ **Тычтым (барысына, башына)** *туп.* Төкереп карау, ис китмәүне белдерә. *Тычтымсана танавыңа!* А.Хәсәнов. *Ә мин көчек кенә әле. Тычтым барысына.* Р.Зәйдулла

**ТЫШ** I *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең күзгә күренеп торган өске ягы; *киресе:* **эч**. *Кошның эченә мәмердәп торган итләч кара җимеш тутырганнар да тегеп куйганнар, аннан соң тышына тәмләткечләр сылап, төче камырга төреп кыздырганнар.* Р.Батулла

2) Киемнең уң ягы, өске ягы; эчлек өстенә тегелгән тукыма. *Иң шәп саналган киемебез – Кутуйның эче ала, ә тышы сары эт тиресеннән тегелгән кыска туны иде.* Х.Туфан. *Ул сиңа кастаньетлар белән биюләр, ул сиңа эче кызыл, тышы кара озын итәкләрне сөйрәп бөтерелүләр, ул сиңа тореадорлар биюе.* М.Мәһдиев

3) Керләнүдән, тузанланудан саклар өчен, мендәр, одеял һ.б.ш. әйберләргә кидерелә торган капчыксыман сүрү; тышлык. *Мендәр тышы, тәрәзә пәрдәсе, галош-фәлән кайтса да шулай.* М.Мәһдиев. *Сабир белән Хәким караваттан бер матрас алып, тышын салдыралар.* Ф.Яруллин

4) Китап, дәфтәр һ.б.ш.ның эче таушалмасын өчен, өске ягына төпләнгән яки тегелгән катыргы, калын кәгазь һ.б.; шуның өстеннән кидерелгән саклагыч чехол, тышлык. *Миңгали карт такта белән бүленеп алынган икенче як бүлмәгә чыкты да, кулына папка хезмәтен үтәгән китап тышы тотып, өстәл янына, Сәгыйтьләр каршысына килеп утырды.* Н.Фәттах. *«Агитатор блокноты»на дәфтәр тышы кидерткән дә шундагы гомуми сүзләрне укып чыкты.* Т.Нәҗмиев

5) Корылманың, бинаның тышкы ягындагы тирә-юнь, ачык һава. *Газинур сикереп торгач аптырап калды: тышта таң аткан иде инде.* Г.Әпсәләмов. *Син инде, әби, тышта бик салкын, кырга чыкма.* М.Мәһдиев

6) Килеш-килбәт, хис-кичерешләрнең чагылышы буларак чырай, йөз. *Шәриф исә, тыштан сер бирмәсә дә, үзенә карата күрсәтелгән игътибарны бик ярата, аңа бик тирәннән шатлана иде.* К.Тимбикова. *Тыштан бик интеллигент кыяфәтле, «шәп» кешеләр.* М.Вәлиев

7) Нинди дә булса чикнең, чикләнгән урынның аргы, икенче ягы. *Минем куркып, каушап калмавымны күргәч, ул, кулымнан тотып, шәһәр тышындагы тау куышына – бер мәгарәгә китерде.* К.Насыйри. *Кайсылары, ганимәт мал күтәреп, кала тышындагы лагерьга ике-өч мәртәбә чыгып керергә өлгерде.* Ф.Зариф

8) *куч.* Төрмә, тоткынлык һ.б.ш. урыннарның тышкы ягындагы тормыш; ирек. *Бер-бер артлы хатлар килеп торса да, тыштан күңелле хәбәрләр юк иде әле.* И.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ. к.* **тышкы**. *Юлчы яңадан тыш якка төште дә, кышлау буйлап, як-ягына карана-карана китте.* Г.Ибраһимов. *Бүлмәнең икенче ягында ишек тә тыш якка таба киерелеп ачылган – өерелеп суык керә.* Б.Рәхимова

◊ **Тышка йөрү** *эвф. к.* **тышка чыгу**. *Хәйдәр ул чак бала-чага гына, кысталган вакытта тышка йөрүләрнең*

*рәтен дә җүнләп белми иде.* В.Имамов. *Дөрес, без, чыннан да, бабайдан калган зур ак итекне сөйрәп, тышка йөри идек йөрүен, ләкин бит баланың чиста, ак йөзе хәзер дә күз алдымда тора.* Ватаным Татарстан. **Тышка чыгу** *эвф.* Табигый хаҗәтне үтәү. *Әнә Ижау кызы Наташа ир-ат белән йоклап алуга ашау-эчү, тышка чыгу кебек гадәти бер шөгыль итеп кенә карый.* Т.Галиуллин. *Тышка чыгу, тәһарәт алу кебек оятлы гамәлләрне башкару үзе бер җәзага әверелде.* М.Әмирханов. **Тыш түгел** *диал.* 1) Исәбе юк түгел (берәр нәрсә эшләргә). *Моны эшләргә тыш түгел*; 2) Нигезсез түгел. *Аның хакындагы сүзләр тыш түгел.* Р.Фәхретдин

**ТЫШ** II *бәйл.* 1) Кемнән яки нәрсәдән башка, кемгә яки нәрсәгә иш, шуның белән беррәттән; гайре. *Анналары бу ару-алҗудан тыш аны монда тагын икенче бернәрсә тотып торды.* Н.Фәттах. *Әле бит аның китабын сатып алудан тыш почта чыгымнары да була.* Ф.Яруллин

2) *Норма, нәүбәт, план, чират, штат* һ.б.ш.ларга карамаган, шуңа өстәмә рәвештә, арттырып, өстәп. *Фабрикалары янгач, чираттан тыш ял биргәннәр үзенә.* Г.Гомәр. *Бик күп колхоз, район җитәкчеләренең мул икмәкне планнан тыш тапшырасылары килде ---.* М.Мәһдиев

3) Гадәттәгечә генә түгел; бик, нык, үтә. *Килә алмаган икән, егетнең сәбәбе чамадан тыш җитди дигән сүз.* А.Гыйләҗев. *Икенче бер кайтуымда мин аны гадәттән тыш йончыган, таушалган кыяфәттә күрдем.* А.Хәлим

4) Кем яки нәрсә катнашыннан башка. *Теләсәң дә туктатып булмый: синең ихтыярдан тыш үзләре агыла...* Ш.Галиев. *Барысы да минем ихтыярдан тыш хәл ителде.* Н.Гыйматдинова

5) Берәр урыннан читтә, башка урында яки башка вакытта. *Әй бит Булат мәктәптән тыш та китапларны күп укый.* Р.Фәизов. *Бу җыелышта сыйныфтан тыш тәрбия эшләрен оештыручы хатын гына (ул Айсинәнең бергә алтын, меңгә җиз икәнен аңлый иде) ык-мык итеп торды.* Н.Көбәш

6) Оешманы белдерә торган сүзләр белән килеп, шунда булмауны, аңа кермәүне аңлата. *Шунысы да игътибарга лаек: заманында гамәли яки штаттан тыш хезмәткәр булып эшләгән сәләтле кайбер яшьләр үзләре үк язучылар булып китте.* Р.Фәйзуллин

**ТЫША́У** I *и.* 1) Ат яки башка хайван утлаганда еракка китмәсен өчен, алгы аякларын бер-беренә бәйли торган бау. *Без дә аның артыннан ирдек, арбаларыбызны рәттән куеп, атларыбызны туардык та, аякларына тышау салып, аланлыкка җибәрдек.* Г.Галиев. *Нишләп мин тизәккә каткан тышау күтәреп йөрим ди!* Д.Салихов

2) Сауганда тибенә алмасын өчен, сыерның арткы аякларын бер-беренә бәйли торган бау. *Сыерның аякларына тышау салу*

3) *күч.* Комачау, рухи богау. *Алар кешегә гомер буе тышау булалар, объектив һәм яхшы булырга комачаулыйлар.* Х.Камалов. *Инде утызны түгәрәкләү алдында торган ир заты булуга карамастан, авыл туфрагында шытып, гап-гади татар гаиләсендә канына сеңгән мокытлык һәрдаим егеткә тышау булды...* *Берничә катлы тышау.* З.Хөснияр

◊ **Тышау көтүе** *иск.* Кулга алынган һәм сак астында кая да булса озатыла торган кешеләр төркеме; этап. *Эшсез һәм паспортсыз ярминкә җирендә йөрү килешми дип, бай баласын тышау көтүе белән (этап белән) озатуны мәслихәт күрделәр.* Ш.Мөхәммәдев. **Тышау салу** Киртә кую. *Аның җанын гарипләргә, музыкасына тышау салырга теләүчеләр әле хәзер дә юк түгел.* Р.Низамиев. *Ыру җыены алдында, анам алдында биргән сүзегезне онытып, бүгеннән үк сез миңа тышау салмакчы буласыз.* Н.Фәттах

**ТЫША́У** II *ф. диал. к.* **тышаулау** (*1 мәгъ.*). *Атны тышап, үзем печән астына кереп яттым.* М.Гафури. *Нинди тылсым мине алган тышап, Үзем өнсез, күңелем талпына.* Н.Арсланов

**ТЫШАУЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **тышаулау**. *Тышауланган Кара бияне китереп бәйләгәч, әткәй тагын учак тергезеп җибәрде.* Н.Гамбәр. *Таллыклар буенда аяклары тышауланган яки өзәңгеләре бәйләнгән атлар чирәм йолкый.* В.Имамов

2) Аякка берәр нәрсә ялгыш уралу, эләгү, буталу. *Аяк астындагы җепләргә тышауланган*

**ТЫШАУЛА́У** *ф.* 1) Эрерәк хайваннарның, гадәттә атларның, сыерларның алгы яки арткы аякларын бер-беренә якын китереп бәйләү, тышау салу. *Үзе сабанга җигелгән атларны җәһәт кенә туарып тышаулады да әле яңарак кына тибеп чыккан үләнле яр буена җибәрде.* М.Хәсәнов. *Тау итәгенә җитүгә, ул атын тышаулады да, җәяүләп, тауга күтәрелә башлады.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Кемне дә булса үзе теләгәнчә эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм итү. *Көнен һәм төнен баш булган курку хисе уйларын да тышаулый, тезгенли, билгеле.* М.Вәлиев. *Кыз мәчеткә табан йөгермәкче иде, ниндидер көч аякларын тышаулады...* Н.Гыйматдинова

**Тышаулап бетерү** Тулысынча тышаулау. *Атны тышаулап бетерүгә, яңгыр ява башлады.* Ш.Маннур

**Тышаулап кую** Тышауланган хәлгә китерү. *Бер эссе көнне, атын тышаулап куеп, киндер арасына кереп йоклаган да шуннан уянмаган.* А.Тимергалин. *Зыялы депутатларны хакимият я кәнәфи, я төшемле урын, я фатир биреп, китабын чыгарып алдый, шул җимнәр ярдәмендә кул-аякларын, акылын тышаулап куя.* Т.Галиуллин

**Тышаулап ташлау** Тиз генә тышаулау. *Хәтта каравыш кыз дип белгән чакта да ул барысына да риза иде: изсен, сытсын, кул-аякларын бәйләсен, ниһаять, ат кебек тышаулап ташласын, тик китмәсен генә иде.* М.Хәбибуллин

**Тышаулап тору** Сөйләү моментында тышаулау; һәрвакыт, даими тышаулау. *Гайфулла абый, иелеп, атын тышаулап торганда, Рәсимә апа тегенең гимнастёркасының сүтелә башлаган җиң төбен күреп: – Сал әле шул гимнәстүркәңне, җиңе өзелеп төшкәнче ямап бирим, – диде.* Г.Галиев. *Хәзер, үзгәртеп корулар чоры башлангач, бездә еш кына социалистик*

*реализм әдәбиятны һәм сәнгатьне тышаулап торды, торгынлыкка алып керде, дигән фикерләр әйтелә.* А.Әхмәдуллин

**Тышаулый башлау** Тышауларга керешү. *Зиннәт абзый, иртә белән торарга җиңел булсын өчен, малайлар атланып килгән атларны тышаулый башлады.* М.Хәсәнов

**ТЫШАУЛЫ** *с.* Тышау кидерелгән, тышауланган. *Атларыбыз пошкырына-пошкырына, тышаулы аяклары белән кушаяклап сикеренә-сикеренә, үлән чемченәләр.* К.Миңлебаев. *Коллар, чуралар тышаулы атларны алып килделәр, җигеләсен җиктеләр, иярлисен иярләделәр.* Н.Фәттах

**ТЫШКАРЫ** *рәв.* Нәрсәнең дә булса тышкы ягына, билгеле чикләрнең тышкы ягына таба. *Бу режим буенча солдатка лагерь эчендә кичке отбойга чаклы йөрергә ярый, рөхсәт белән батальоннан тышкары чыгарга да мөмкинлек бирелә.* Ш.Маннур. *Икенче яктан, теге яки бу сүзнең изоглоссасы аерым бер телдән тышкары чыкмаса, бу аның этимологиясен шул телнең үзеннән эзләргә кирәклеген искәртә.* Р.Әхмәтьянов

**ТЫШКЫ** *с.* 1) Берәр нәрсәнең, корылманың һ.б.ш. тышында, аннан читтә булган. *Күзләре дә аның, ничектер, эчкә киткән, гүя тышкы дөньяга түгел, ә күңелендәге уйларына төбәлгән.* Ә.Еники. *Тышкы якта, бар тарафны оетып, җиргә куе караңгылык сыенган.* А.Вергазов

2) Читтән булган, чит кешеләрдән, чит мохиттән булган. *Әйе, бу аңа үзенең тынычлыгын, саулыгын тышкы тәэсирләрдән, икенче төрле әйтсәк, тәҗрибәсез һәм акылсыз җитәкченең һөҗүменнән саклап калу өчен кирәк.* А.Вергазов. *«Арыш анасы» составындагы алкалоидларның күләме күп кенә тышкы тәэсирләргә дә бәйле.* Агулы үсемлекләр

3) Җиңел эчке кием өстеннән киелә торган. *Мәрьям, үзенең тышкы киемнәрен тәмам ташлап, кечкенә бала шикелле Зыяның алдына утырып, икесе бер тун эчендә улдыгы хәлдә, яңакларын Зыяның йөзенә куеп, үзенең бу өч көнне үткәрүдә күргән газапларын сөйләмәктә иде.* Г.Ибраһимов. *Кызына эчке һәм тышкы киемнәр, Әлфиягә кан басымын тиешле ноктада тота торган кул сәгате, тәмле-томлы әйберләр алып кайткан.* Т.Галиуллин

4) Берәр предмет яки күренешнең чын асылына карамаган, чын асылын чагылдырмаган, тыштан ук, беренче карашка ук күренә торган. *Тышкы тынычлыгы астында дәртле һәм акыллы, зирәк юнәлеш бирүгә сәләтле хатын яшеренгән булып чыкты.* Т.Галиуллин. *Мин аның күңел тупаслыгыннан, тышкы матурлык астындагы эчке ямьсезлегеннән җәфа чигәм бугай.* М.Вәлиев

5) *мат.* Өчпочмакның (күппочмакның) теләсә нинди ягын дәвам иттергәндә, күрше як белән ике арада барлыкка килә торган (почмак тур.). *Белүебезчә, өчпочмакның бер ягы дәвам ителсә, тышкы почмак барлыкка килә.* Мәгариф

6) *күч.* Башкаларны шаккатыруга исәпләнгән. *Тышкы ялтыравыклы гүзәллекне маңгай күзләре сау булганнарның барысы да күрә, ә менә эчкә яшерелгән гүзәллекне күрү өчен, маңгай күзе генә җитми, аның өчен күңел күзеңнең ачык булуы, эчке тәрбия, затлы булу шарт.* Р.Батулла. *Мин монда тышкы эффектлар турында да әйтмәкче булам.* Р.Миңнуллин

7) Чит дәүләтләргә, оешмаларга мөнәсәбәтле; чит дәүләтләр белән бәйле булган. *Иван V идарә иткән елларда Россиянең тышкы сәясәтендә дә һәм ил эчендә дә туктаусыз сугышлар, рәхимсез кан коюлар булып тора.* Г.Камал. *Әлеге проблемаларның территориаль һәм этник яклардан тышкы мөнәсәбәтләргә бәйле булганнары да бар.* Р.Сафин

8) Чит дәүләтләрдә булган, чит дәүләтләрдә гамәлдә булган. *Дөрес, соңгы 2–3 елда җитештерүчәнлек һәр тармакта кими башлый, әмма моны, нигездә, башка илләрнең, ягъни тышкы базар мөнәсәбәтләренең үзгәрүе белән аңлаталар.* Т.Нәҗмиев

9) Чит дәүләтләрдән булган, чит дәүләтләрнеке булган. *Аяусыз изүгә түзми баш күтәргән башкортларны меңәрләп-меңәрләп үтерә, аса-кисә, авылларына ут үрләтә, хатын-кызларын, балаларын коллыкка ала да, инде килеп тышкы дошман басып керсә, ярдәм итегез, дип оран сала.* З.Мурсиев

**ТЫШЛАМА** *и.* Бинаның, корылманың тышкы стенасына матурлык, җылылык һ.б.ш. максатлардан беркетелә торган өстәмә катлам; шуның өчен кулланылган панель, такта һ.б.ш. төзелеш материалы. *Фирғалиләр бригадасы төп корпуста, генератор куелачак шактый биек урындагы тимербетон корылышта такта тышламаларны ала иде.* С.Рафиков. *Болары инде матурлык хакына гынадыр кебек: парапетлар, тышлама плитәләр урнаштыру, ябыштыру.* Ә.Баян

**ТЫШЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **тышлау**. *Дерматин белән тышланган ишек тартканчы ук ачылып, безне яшь кенә лейтенант каршы алды.* М.Мәһдиев. *Егет, кабина түбәсеннән асылынып төшкән чуклы пәрдәләргә, бәрхет белән тышланган утыргычларга, барча яктан елмаеп карап торучы ярымшәрә кызларга карап, канәгать елмайды, каш сикертте.* Р.Вәлиев

**Тышлана башлау** Тышланырга тотыну. *Коммунистлар динне бетерү өчен ни генә кыланмады – нәтиҗәсе шул: тәрәзәләребезгә тимер челтәрләр куела, ишекләребез тимер белән тышлана башлады, кичләрен урамга чыгу хәвефле эшкә әйләнде.* Т.Әйди

**Тышланып бетү** Тышлану төгәлләнү. *Хәзер инде аларның бергә утырып тамак ялгый торган кухнясы, ике йокы бүлмәсе, тагын бер зур ял бүлмәсе дә такта белән тышланып бетте.* Р.Сәгъди. *Абыйлар эшли торган йорт тышланып бетеп килә.* Мәйдан

**Тышланып килү** Әкренләп, азазлап тышлану. *Бер ай элек каркастан гына торган бина тышкы яктан плитә белән тышланып килә.* Идел таңнары

**ТЫШЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **тышлау**. *Бик матур, кәнәфиләрен, урындыкларын да – һәммәсен берочтан шуның белән тышлатканнар.* Г.Камал. *Шуннан уйлап-уйлап тора да, киоскысын эчке яктан тышлатып, көнлек керемен, ягъни кәгазь акчаларны, целлофан*

*капчыкларга салып, ике арага тутырып бара башлый.* Р.Миңнуллин

**Тышлата башлау** Тышлатырга тотыну. *– Җәй җитүгә тышлата башларга кирәк инде, тагын сузып булмый, – дип куйды эти.* М.Мәһдиев

**Тышлатып алу** Тиз арада тышлату. *Җимерекләре күренмәсен дип, ике бүлмәле фатирыбызны пластик белән тышлатып алган идек.* Ватаным Татарстан

**Тышлатып бетерү** Тышлатуны төгәлләү; барысын да тышлату. *Йортын тышлатып бетерүгә ялга китәргә планлаштырып тора ул.* И.Нуруллин

**ТЫШЛА́У** *ф.* Берәр нәрсәне тукыма, калай, такта һ.б.ш. нәрсәләр белән каплау. *Веранданың эчен матурлап сырланган такталар белән тышлады.* Ф.Яруллин. *Шуның белән идәндиварын тышлады, хәтта ки аны түшәменә кадаклаучылар да булды.* Н.Гыйматдинова

**Тышлап алу** Тиз арада тышлау. *Иң зур чыгымнар сорый торганы – фасадны сайдинг белән тышлап алу икән.* Ватаным Татарстан

**Тышлап бетерү** Тышлауны төгәлләү, барысын да, тулысынча тышлау. *Мәктәпнең тышкы фасадын инде тышлап бетереп, яңа пластик тәрәзәләр урнаштырганнар.* Авыл офыклары

**Тышлап бирү** Кем өчендер тышлау. *Дачасын тышлап бир!..* Р.Кәрами. *Матур итеп бушлай тышлап бирделәр.* Шәһри Казан

**Тышлап җибәрү** *к.* **тышлап кую**. *Иске булса да, бүрәнәләрен чыкылдап торган нарат такта белән тышлап җибәрсәң, ике гомергә чыдарлык.* Ә.Гаффар

**Тышлап кую** Тышланган хәлгә китерү. *Китапларыңны тышлап куйган идем ---.* К.Насыйри. *Әмма йортларны гасыр ярым элек тышлап куйган такталар нык кына череп беткән, байлар яллап ясаткан бизәкнәкышлар яртылаш сынып төшкән.* Мәдәни җомга

**Тышлап чыгу** Барысын да тышлау, тулысынча тышлау. *Аның каравы менә дигән десятка алды, агач йортын кирпеч белән тышлап чыкты.* З.Мәхмүди

**Тышлый башлау** Тышларга тотыну. *Хәзер вольерларны ясалма таш, агач белән тышлый башлаганнар.* Шәһри Казан

**Тышлый тору** Берәр эш-хәлгә кадәр тышлау. *Яңгырлар ява башлаганчы тышлый торабыз, дип сөйләшкән идек.* Р.Вәлиев

**ТЫШЛЫ** *с.* Тышы булган, тышланган. *Юка тышлы китап чыгарып, зур шагыйрь саналып була димени!* Р.Фәйзуллин. *Абый кызыл тышлы калын китап караштырып утыра.* Г.Якупова

**ТЫШЛЫК** *и.* **1.** 1) Калын өс киеменең тышы I (*2 мәгъ.*) өчен махсус тукыма яки күн. *Каяндыр тышлык, эчлек, мамык юнәтеп, өйгә үзебезнең авыл тегүчесе Галәттин абыйны керттеләр дә миңа бишмәт тектерделәр.* Ш.Маннур. *Җитәкче Шомбай токымы гына алдатмады: туннарын-бүрекләрен әйләндереп киделәр, һәм кызыл тышлык зәңгәр эчлек белән урын алмашты.* Р.Зарипов

2) Керләнүдән, таушалудан, тузаннан саклау өчен, мендәр, юрган һ.б.ш. өстеннән кидерелә торган, тукымадан тегелгән капчыксыман сүрү; чехол. *Старшина одеяллар, ак җәймәләр, түшәк тышлыклары өләшә.* Г.Әпсәләмов. *Аларның [мендәрләрнең] чигүле тышлыклары шулкадәр дә күзне иркәләп тора, кайдадыр җан түрендә татарлыгым өчен горурлык хисе баш калкытып куйды.* Г.Гыйльманов

3) Китап, дәфтәр кебек нәрсәләрнең кәгазь, катыргы, клеёнка һ.б.ш. материалдан эшләнгән беренче һәм соңгы бите. *Алар артында тышлыклары дымнан кабарган китаплар күренде.* А.Гыйләҗев. *Абзыйсының математика һәм матур язу дәфтәрләренең чагыштырмача чиста тышлыкларын тимер атламаларыннан аерып алды.* А.Хәлим

4) Паспорт, билет, аттестат һ.б.ш. документларны саклау өчен, шул документ зурлыгындагы махсус тыш. *– Мәле, кесәңә салып куй шуны, кирәкярагыңа тота торырсың! – дип, әтисе Фәләхкә, паспорт тышлыгы арасына кыстырып куйган җиреннән алып, дүрт данә йөзәр сумлык сузды.* В.Нуриев. *Илсөяр калтыраган куллары белән тиз генә иңендәге сумкасын ачып, андагы билет тышлыгын капшап карады: урынындамы, янәсе.* Ә.Сафиуллин

5) Ертылудан, пычранудан, тырналудан, таушалудан саклау максаты белән төрле әйберләрне тышлау яки салып кую өчен кулланыла торган катыргы, пластик, силикон һ.б.ш. тыш. *[Кыз] Кәгазьләрне картоннан ясаган тышлык эченә салып, тышлыкка фамилиямне язып куйды: – Сессия киләсе дүшәмбедә башлана.* М.Юныс. *Тышлык калынлыгы аркасында телефон кыза, ә бу – аккумулятор өчен бик зыянлы, ди белгечләр.* Сабантуй // Гомумән, матуррак, яхшырак, затлырак күрсәтер өчен, нәрсәгә дә булса кидерелә торган тыш. *Ул шунда ук хөрмәтле кунагы янына барып җитә, мөлаем генә исәнләшә, матур тышлык эченә куйган менюны тәкъдим итә һәм чиста өстәлне тагын бер кат сыпыргалап ала.* Ә.Еники. *– Сөйли белүләре шундый гына: кулларына, матур тышлыкка тыгып, концерт программасы тотып чыкканнар бит әле әнә, – дип көлде ул.* Мәйдан

6) Бина яки корылманың тышкы стенасын тулысынча каплаган такта, калай, сайдинг һ.б.ш. материал. *Тышлагыч плитәләр һәм асылма түшәмнәр, кысалап, тышлык белән ныклап беркетеп ясала.* Төзү материаллары. *Рифат үз вакытында йорт тышлыгын, тәрәзә кәрнизләрен, чарлакларын, капка-коймаларын агачтан уеп ясаган чәчәк-бизәкләр белән чуарлап бетергән иде.* Ватаным Татарстан

7) Бәлеш, өчпочмак, гөбәдия кебек ризыкларның тышы өчен әзерләнә торган камыр. *Тышлык куна тактада бераз хәл җыйгач, аны җәеп, тигезләп-түгәрәкләп эчлеген тутырды.* Н.Гыйматдинова. *Ә хәзер тышлык камыры әзерлик.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тыш (*2, 3 мәгъ.*) тегәрлек. *Тышлык материалым бар иде сандыкта, шуны тотарбыз инде.* И.Галиева. *Ул тышлык драпны күптән алып куйган булган.* Кызыл таң

2) Бина һ.б. тышлау өчен яраклы, тыш (*1, 4 мәгъ.*) ясау өчен билгеләнгән.

*Тышлык калайлар да шул вакытта ук юкка чыккан, аны хәбәр итүче генә булмаган.* И.Нуруллин. *Аларның тышлык тактасы җитәрлек булмагандыр ---.* Ф.Яруллин

**ТЫШТАН** *рәв.* 1) Үз-үзен тотышы яки сүзләре белән. *Күңелемнән тотып ашарлык дәрәҗәдә ачулансам да, тыштан берни дә сиздермәдем җиңгигә.* В.Нуруллин. *Ну, Һидиятуллин абый, тыштан болай хәрбиләрчә кырыс күренсәң дә, Макаренко кебек педагогларны уздырырлык акыл булган бит үзеңдә!* Р.Низамиев

2) *күч.* Ихлас, чын күңелдән булмыйча, тышкы яктан гына; кешеләр алдында. *Мин эчемә ут йотып, тыштан көлеп яшәгән артисткага әйләндем.* М.Маликова. *Тыштан гына бер-берсен яманлаган булалар, кеше күрсен дип.* Р.Камал

3) *күч.* Берәр нәрсәнең, күренешнең асылын тикшермичә, өстән-өстән. *Тыштан караганда, тормыш әйбәт, шома, музыкалы, чәчәкле.* Х.Камалов. *Тыштан караганда, барысы да шома гына үтте.* М.Кәбиров

◊ **Тыштан ялтырау, эчтән калтырау** 1) Тышкы яктан гына яхшы күренеп, чынлыкта бик үк сыйфатлы, яхшы булмау турында. *Әйтәсе сүзем шул: әдәби әсәрләр дә тыштан ялтырап, эчтән калтырап торган продукция булмасын иде.* Т.Нәҗмиев. *Тыштан ялтырап, эчтән калтырап яши бирдек.* М.Кәбиров; 2) **Тыштан ялтырап, эчтән калтырап йөрүче** Асылда булдыксыз яки яраксыз булып та, үзен булдыклы, яраклы итеп күрсәтергә тырышу. *Билгеле инде, тыштан ялтырап, эчтән калтырап йөрүчеләр алар.* И.Нуруллин. *Тыштан ялтырап, эчтән калтырап йөрүчеләр дә бар.* С.Поварисов

**ТЫШЧА** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса тышы, тышкы яктан каплап торган катламы. *Беренчесе: ипине мичтән алып суынырга куйганда, момент (мизгел) ычкындырылган, һәм ипинең кетердәвекле кызгылт тышчасы йомшагыннан аерылган.* М.Мәһдиев. *«Кабык» сүзе татарда нәрсәнең дә булса тышчасын белдерә.* Н.Фәттах

2) *тех.* Төрле формадагы куышлыкның юка каты тышы, сүрүе. *Тышчалар теориясе*

3) *физ.* Атом төшенең тышкы сүрүе. *Җаннан моңлы дога чыга, Атом тышчасын ватып!* Г.Гыйльманов. *Атом төштән һәм тышчадан тора*

4) *биол.* Күзәнәк эчендәге тере матдәнең юка ярыдан торган тышкы катламы, тышы. *Күзәнәкләрнең тышчасы шартлап ярыла да, алар үрчи башлый.* М.Маликова. *Наратбашларның агулы үзлеге күрән (осока) белән бергә ашалганда көчәя, һәм әлеге күренеш, лайлалы саклагыч тышча җәрәхәтләнү сәбәпле, эчәкләрнең сеңдерүчәнлеге көчәю белән аңлатыла.* Агулы үсемлекләр

5) *биол.* Тере матдәне тыштан каплап торган яры, элпә. *Бөре тышчасы яфракчыкка: «Ярый, хуш!»* Г.Рәхим. *Каракучкыл яшел төстәге икеләтәөчләтә каурыйсыман яфракларының ас ягы ялтыравык тышча белән капланган.* Агулы үсемлекләр

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса күренә торган билгеле ягы; нәрсәнең дә булса асылын аңларга комачаулый торган тышкы билге. *Әмма бүген җыелыш рәсми тышча кысасыннан бер дә чыкмый.* Х.Камалов. *Татар телендә төрле чаралар уздырылса да, болар тышча гына.* И.Ядкәрова

**ТЫШЫНДА** *бәйл.* Берәр нәрсәдән читтә, аерым. *Хәзергә кадәр алар ул эшне игътибар тышында калдырганнары юк иде.* Ш.Камал

**ТЫЮ** *ф.* 1) Берәр нәрсә эшләргә рөхсәт итмәү. *Иске идарә Төркестанда мәктәп ачуны бөтенләй тыйган иде.* Г.Исхакый. *Чишмә буена барудан әткәм мине тыйды.* Р.Батулла

2) Нәрсәне дә булса житештерүне, куллануны рөхсәт итмәү, берәр нәрсә эшләргә юл куймау. *Хәер, Дәүләт Думасының безнең телебезгә мөнәсәбәте билгеле: татар язуын латин графикасына күчерүне тыйган депутатлар җыены бит ул!* Р.Фәйзуллин. *Уйлап караганда, тәңречелек дуңгыз итен ашауны тыйган, һәм бу гамәл соңрак ислам диненә күчкән, дип әйтергә була.* И.Хуҗин

3) Үз-үзен яки башкаларны берәр нәрсә эшләүдән, берәр төрле хис-кичерешләрен белдерүдән тотып калу, туктату. *Асаф үзен тыйды, әмма теге вакыйганы сөйләмәде.* М.Мәһдиев. *Көчсез көрәк сындыра, дигәндәй, Дамир, мылтык белән янау һич тә килешми, дип, үзен ныклап тыйды.* С.Шәрипов

4) Кемнең дә булса, нәрсәнең дә булса хәрәкәтен туктату яки киметү. *Саҗидә, дилбегәне җан көченә үзенә тартып, атны тыярга тырыша.* М.Галәү. *Шалденконың күзләре очкынланып китте, ул автоматын күтәрде, ләкин Краснов атудан тыйды.* Г.Әпсәләмов

**Тыеп килү** Озак вакыт дәвамында тыю. *Зөфәр тирән итеп бер сулап куйды һәм, аз гына тынып торганнан соң, моңарчы тыеп килгән дулкынлануын телефон аша җиткерергә теләгәндәй, учы белән трубканы ышыклап, акрынйомшак кына итеп әйтте: – Рәшидәм, тыңлыйсыңмы... мин сине бик-бик сагындым!* Ә.Еники. *Аларга ташланудан үзен көч-хәл белән тыеп килде Мортазин.* В.Имамов

**Тыеп тору** Гел, һәрвакыт тыю; вакытлыча тыю. *Нәҗипнең, сикереп торып, тимер юлны шартлатасы, әзгә генә тавышларны тыеп торасы килгән чаклары бик күп булды.* А.Гыйләҗев. *Трубканы алып, ул бәндәнең кемлеген ачыклаудан мин үземне көчкә тыеп тора идем.* А.Әхмәтгалиева

**Тыя башлау** Тыюга күчү, тыюга хәтле барып җитү. *Хезмәт ияләренең, җитмәсә, колониядәге кара халыкның күзе ачылудан, милли аңы уянудан хәвефләнгән патша түрәләре саклану чаралары күрә: матбугатны бер-бер артлы яба, татарларга башка милләт балаларын укытуны тыя башлый.* Т.Әйди

**Тыя килү** Озак вакыт дәвамында тыю. *Һаман шул тыйнаклыгым тыя килде.* Ф.Яруллин. *Нечкә күңелле, дөньядагы һәрбер мизгелгә шатланырга өйрәнгән Зәринә табигатьтә йөрергә, тормыш турында сөйләшергә, шаярырга, көлергә ярата, ә Рифаты аны гел тыя килә.* А.Мансуров

**Тыя төшү** Бераз тыю; тагын да тыю. *Нигә [атын] шулкадәр куа икән соң бу абзый? Бераз тыя төшсен*

*иде: урамны атлатып кына узса да ярый бит.* Г.Бәширов. *Сәет саксыз энекәшен кисәтмәкче булып, аргамагын берникадәр генә тыя төшкән иде, Вәлидә ханбикә аның кул астына хуш исләре аңкып торган затлы кульяулык кыстырып өлгерде.* В.Имамов

**ТЬЮ-ТЬЮ** *иярт.* Пуля һ.б.ш. нәрсәләр бик зур тизлектә сызгырып үткәндә чыккан нечкә тавышны белдерә

**ТЬЮ-ТЬЮ́ ИТҮ** *ф.* Нечкә сызгырган тавышлар чыгару. *Бераздан снарядлар еш кына төшкәли башлап, өстебездә өзлексез тью-тью итеп пулялар сызгырырга кереште.* Ш.Усманов

**ТЮ́БИК** *и. фр.* Буяу, крем, желе, җилем кебек пастасыман нәрсәләр тутырылган, йомшак калайдан яки пластмасстан эшләнгән торба рәвешендәге кечерәк савыт. *Пакетын бушата башлагач, аннан бер ипи, ике таяк колбаса, өч шешә сөт, дүрт тюбик теш пастасы --- чыкты.* Ватаным Татарстан

**ТЮК** *и. төрки* Йон, тукыма һ.б.ш. шундый йомшак нәрсәләрнең кысып бәйләнгән зур төргәге. *Анда да кешеләр мәш киләләр: сүс бәйләмнәрен үлчәп, олы-олы тюклар ясыйлар.* М.Хәсәнов. *Әзерләп, тюкларга бәйләп куелганнары да бар печәннең.* Ватаным Татарстан

**ТЮКЛА́У** *ф.* Нәрсәләрне дә булса тюкларга бәйләү, шулардан тюклар ясау. *Безнең күршедә бердәнбер тыныч характерлы судно – Төркиянең «Карадәниз» исемле сәүдә пароходы – тюклаган сарык тиреләре төяп ята.* М.Мәһдиев. *Ул елны безнең колхоз Владимир өлкәсендә салам тюклады.* Безнең гәҗит

**Тюклап бетерү** Тюклау эшен тәмамлау

**Тюклап тору** Әле, хәзерге вакытта тюклау

**Тюклый бару** Бер-бер артлы тюклау

**Тюклый башлау** Тюкларга тотыну

**ТЮКЛЫ** *с.* Тюкларга бәйләнгән, тюкларга төрелгән; төргәкле. *Тюклы салам. Тюклы товар. Тюклы тукыма*

**ТЮЛЕНЬ** *и. рус<саам зоол.* Ишкәгаяклылар семьялыгыннан кыска аяклы, каты йон белән капланган имезүче диңгез хайваны. *Диңгезне каплап алган боз өстендә ак аюлар уйный, симез тюленьнәр шаяра.* А.Алиш. *Ак аю, тюлень аулаганда, посып кына җилгә каршы яктан үрмәли, кара борынын тәпие белән томаларга да онытмый.* Ш.Галиев

**ТЮЛЬ** *и. фр.* **1.** Челтәрләп бизәлгән җиңел үтәкүренмәле тукыма. *«Эре чәчәкле тюль сайлаганда, автобазадагы Софья Матвеевна әйтмешли, иптәш Сәйдәшев бер-бер хатын-кыз белән киңәшмичә калмагандыр әле» дигән уй күңелемне тагын җылытты.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Уртадагы тюль пәрдә аша океан дулкыннары уйнаклаганы күренә.* Т.Әйди

**ТЮ́ЛЬКА** *и. рус* Сельдь балыклар семьялыгыннан вак промысел балыгы. *Ә килькинең йөз граммы биш тиен иде. Шуның өчен алты тиенгә ике йөз грамм тюлька алу отышлырак иде безнең өчен. Гади арифметика. Экономия!* К.Сатиев. *Бу отрядка караган балыклар арасыннан океан сельде, сардина, иваси, тюлька иң тәмле итле балыклар санала.* Т.Шакирова

**ТЮЛЬПАН** *и. фар.* Лалә, кызалак. *Тюльпан үстерү XVIII гасырда солтан Әхмәд III гасырында аеруча модага керә.* А.Тимергалин. *Тюльпан чәчәгенең үзәген зур җимешлек алып тора, аның кыска баганачыгы очында өч аерчалы җимешлек авызчыгы була.* Гомуми биология

**ТЮРКО́ЛОГ** *и. рус* Төрки халыкларның телләрен, тарихларын һәм мәдәниятен өйрәнүче галим; тюркология белгече. *Тюрколог С.Е. Малов төрки телләрне аерата яшь итеп күрсәтергә тырыша.* Н.Фәттах

**ТЮРКОЛО́ГИК** *с.* Тюркологиягә караган. *Тел секторында язылган һәм дөнья күргән хезмәтләр Татарстанда гына түгел, башка тюркологик үзәкләрдә дә дан казандылар.* Фән һәм тел

**ТЮРКОЛО́ГИЯ** *и. рус* Төрки халыкларның телләрен, тарих, әдәбият, фольклор һәм мәдәниятен өйрәнә торган фәннәрнең җыелма атамасы. *Латыйф Җәләй – тюркологиягә зур өлеш керткән галим. Алтаистикага һәм тюркологиягә кагылышлы хезмәтләрнең күргәзмәсе үзенең байлыгы, төрлелеге белән шаккатырды.* Х.Миңнегулов. *Тюркология корылтаеннан соң Татарстан матбугатында кискен полемика башлана.* Б.Хәкимов

**ТЯГАЧ** *и. рус* Авыр йөк, тагылма яки башка шундыйларны тарта торган зур егәрле машина яки трактор. *Урам буйлап авыр туплар сөйрәп тягачлар шуыша, машиналар хәрәкәтләнә.* М.Хәсәнов. *Немецлар тягачларын кабызды, аңа каяндыр снаряд төяп, пушкалар янына китерәләр.* Х.Камалов

## ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Справочное издание

# ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

(на татарском языке)

**Том V**

**(С – Т)**

Редактор *Н.К. Нотфуллина*
Корректоры: *Н.К. Нотфуллина, Р.К. Сагдиева*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 110. Уч.-изд. л. 93,2
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20